
TKH

АКАДЕМИЯ НАУК СССР
КАЗАНСКИЙ ФИЛИАЛ
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСТОРИИ
им. ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА

ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В ТРЕХ ТОМАХ



К-С

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
1979

СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
КАЗАН ФИЛИАЛЫ
ГАЛИМҖАН ИБРАһИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ һӘМ
ТАРИХ ИНСТИТУТЫ

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ АҢЛАТМАЛЫ СҮЗЛЕГЕ

ӨЧ ТОМДА



К-С

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1979

4С(Тат)(03)
Т23

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Галимжан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты Гыйльми советы карары нигезендә басыла

Төзүчеләр:

И. А. Абдуллин, Г. Х. Ахунҗанов, С. Б. Вахитова, Ф. М. Газизова, Ф. А. Ганиев, Р. Р. Мингулова, М. Г. Мөхәммәдиев, Ш. С. Ханбикова, Р. Г. Әхмәтьянов.

Редколлегия:

Л. Т. Махмутова, М. Г. Мөхәммәдиев, К. С. Сабиров, Ш. С. Ханбикова.

Нәшрият редакторлары:

Г. Г. Абдрахманова, Р. А. Зиляева

Т $\frac{70105-034}{М132(03)-79}$ 287 — 78

© Татарстан китап нәшрияты, 1979

РЕДАКЦИЯДӘН

„Татар теленең аңлатмалы сүзлеге“ өч томнан тора. А — Й хәрефләрен эченә алган I томы 1977 елда басылып чыкты. II томга К — С хәрефләренә башланган сүзләр кертелде.

II томны төзүдә катнаштылар: И. А. Абдуллин — П(пи I — пүчтәк) хәрефе; Г. Х. Ахунҗанов — С хәрефе; С. Б. Вахитова — К (к — карават, квадрант — кингстон), Н, Р (ризә — рөшди) хәрефләре; Ф. М. Газизова —М (мирас — мүкәләп) хәрефе; Ф. А. Ганиев — К (куш — кһекһе), Л хәрефләре; Р. Р. Мингулова — Р (Р — ридикюль) хәрефе; М. Г. Мөхәммәдиев — К (киндер — коръән), М (М — миражлану), О хәрефләре; Ш. С. Ханбикова — К (коры — кукшин) хәрефе; Р. Г. Әхмәтьянов — К (каравыл — каһәрләнү, кул — кучты), П (п — пешү) хәрефләре.

Сүзлекнең II томын редакцияләделәр: Л. Т. Махмутова — К хәрефен („к“ дән „куш“ сүзенә кадәр), М — С хәрефләрен тоташтан; М. Г. Мөхәммәдиев, Ш. С. Ханбикова һәм К. С. Сабиров — тулысынча.

Сүзлеккә кагылышлы белешмә материаллар I томда бирелде.

Сүзлек турындагы фикер һәм теләкләрне түбәндәге адреслар белән җибәрергә мөмкин:

Казань — 420111, Лобачевского, 2/31, Институт языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова Казанского филиала Академии наук СССР яки

Казань — 420084, Баумана, 19, Татарское книжное издательство.

ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

а. — алмашлык
аваз ияр. — аваз ияртеме
авиа. — авиация
артык. — артыклык (дәрәҗәсе)
а.-х. — авыл хуҗалыгы
аз. — азайту (дәрәҗәсе)
анат. — анатомия
аныкл. — аныклау (кисәкчәсе яки теркәгече)
археол. — археология
астр. — астрономия
баш килеш. бәйл. — баш килеше белән килгән бәйлек
берл. — берлек сан
бил. — билгеләү (алмашлыгы)
биол. — биология
бор. — борынгы (сүз)
бот. — ботаника
б-сез. — билгесезлек (алмашлыгы)
бәйл. — бәйлек
бүл. — бүлем (саны)
бүлг. — бүлгәләүче (теркәгеч)
гади с. — гади сөйләм
геогр. — география
геол. — геология
геом. — геометрия
диал. — диалекталь сүз
дини. — дини сүз
дәр. — дәрәҗә
жарг. — жаргон
зат — зат (алмашлыгы)
зоол. — зоология
з-сыз — затланышсыз (фигыль)
и. — исем
игътб. — игътибарсыз караш
ик. — икеләнү (кисәкчәсе)
инк. — инкяр (кисәкчәсе)
ирк. — иркәләү сүзе
ирон. — ироник мәгънәдә
иск. — искергән (сүз)
иял. килеш. бәйл. — иялек килеше белән килгән бәйлек
йөкл. — йөкләтү (юнәлеше)
к. — кара
каб. — кабатлау (дәрәҗәсе)
каб. форм. — кабатлаулы формада
кайт. — кайтым (юнәлеше)
карг. — каргау (каргыш) сүзе
карш. — каршылык (теркәгече)
кер. сүз — кереш сүз
кеч. — кечерәйтү
килеш. — килеш (формасында)
ким. — кимлек дәрәҗәсе
кимс. — кимсетеп әйтү
кис. — кисәкчә
кит. — китап теле
көч. — көчәйткеч (кисәкчә)
күпл. — күплек (сан)
күрс. — күрсәтү (алмашлыгы)
күч. — күчмә мәгънәдә
лингв. — лингвистика
лог. — логика

мат. — математика
махс. — махсус термин (антропология, архитектура, аучылык, бакчачылык, бактериология, биохимия, бухгалтерия, ветеринария, геодезия, гидрология, гидромеханика, дипломатия, диңгезчелек, кинематография, коммерция, кортчылык, кулинария, метеорология, механика, минералогия, оптика, полиграфия, радиотехника, тимерюл, типография, топография, тукучылык эше, фармакология, шахмат уены, юридик һ. б. өлкәләргә караган терминнар)
мед. — медицина
миф. — мифология
муз. — музыка
мыск. — мыскыллау
мәгъ. — мәгънәдә
мөн. — мөнәсәбәтлек (сүз)
неол. — неологизм
обр. ияр. — образлы ияртем
пед. — педагогика
психол. — психология
полит. — политик термин
рәв. — рәвеш
рәс. — рәсми
с. — сыйфат
сан — сан
сир. — сирәк кулланышта
сор. — сорау (алмашлыгы)
спорт — физкультура һәм спорт
сын. — сынлы (сәнгать)
сәб. — сәбәп (теркәгече)
сәнг. — сәнгать
сөйл. — сөйләү телендә
тар. — тарихи
тарт. — тартым (алмашлыгы)
театр — театр сәнгатенә караган сүз
теркәг. — теркәгеч
тех. — техника термины
тирг. — тиргәү сүзе
туп. — тупас сүз
тәрт. — тәртип (саны)
төш. — төшем (юнәлеше)
урт. — уртаклык (юнәлеше)
у.-вак. — урын-вакыт килеше
ф. — фигыль
физ. — физика
физиол. — физиология
филос. — философия
фольк. — фольклор
форм. — формасында
функ. — функция
хим. — химия
хупл. — хупламау
хур. — хурлау
хәб. — хәбәр (функциясендә)
хәб. сүз — хәбәрлек сүз
хәрби — хәрби сүз
чаг. — чагыштыру
чик. — чикләү (кисәкчәсе)
чыг. килеш. бәйл. — чыгыш килеше белән килгән бәйлек
шаярт. — шаярту сүзе
шелт. — шелтәләү сүзе
шигъ. — шигъри сөйләмдә
шөбһ. — шөбһәләнү
энд. — эндәш сүз
эвф. — эвфемизм
экон. — экономика
эпист. — эпистоляр стиль
этн. — этнография
юг. — югары стиль
юкл. — юклык (алмашлыгы)
юн. — юнәлеш
ярд. — ярдәмче (фигыль яки сүз)
ы. — ымлык
әд. — әдәбият термины
җый. — җыйма (исем)
җыр. — халык җыры
җыю. — җыючы (теркәгеч)

ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

‖ — сүзнең мәгънә төсмерләрен аера торган билге.
| — сүзнең грамматик һәм стилистик кулланыш үзенчәлекләрен аерып күрсәтә торган билге.
◇ — фразеологик әйтелмәләрне аерып бирү билгесе.
▭ — иллюстрация мисалларында сүз тезмәләрен җөмләләрдән аера торган билге.
- - - — җөмләләрне кыскарту билгесе.

АЛФАВИТ

А а	И и	Р р	Ш ш	Ә ә
Б б	Й й	С с	Щ щ	Ө ө
В в	К к	Т т	Ъ ъ	Ү ү
Г г	Л л	У у	Ы ы	Җ җ
Д д	М м	Ф ф	Ь ь	Ң ң
Е е	Н н	Х х	Э э	Һ һ
Ж ж	О о	Ц ц	Ю ю	
З з	П п	Ч ч	Я я	

К

К Татар алфавитында унберенче хәреф.

КААН *и. тар. к.* каган. *Җирдә хөкем сөрә шул чакларда әллә нинди татар кааны; Тирә-якка мәгълүм, мәшһүр була ул каанның гайрәт атагы.* Гыйффәт Туташ.

КААНЛЫК *и. тар. к.* каганлык. *Бу суык хәнҗәр минем Өзгәләр бәгъремне сырган Бар әсирлек бауларын, Теткәләр алдымдагы барлык Каанлык тауларын!!* Һ. Такташ.

КАБА *и.* 1. Җеп эрләү өчен йон, сүс, мамыкны беркетә торган тараклы такта җайланма. *Сүс кабасы. Йон кабасы.* □ *Зәйнәпнең апайлары кичләр утырып, җитенне кабага элеп, орчык әйләндерә, җеп эрли башладылар.* Дәрдмәнд. *Гөлмөнәвәрә әби дә, --- орчык белән каба алып, җеп эрләргә тотынды.* М. Гали. || *с. мәгъ. күч.* Зур, кин. *Каба сакаллы.* □ [*Насрый*] *йөргән вакытта --- озын һәм каба кулларын һич хәрәкәтләндермичә --- акрын һәм әре генә атлап йөри иде.* Ш. Камал.

2. Агач суканың төрәнен беркетеп куя торган кисәге.

Каба агачы — *к.* каба төбе (1 мәгъ). *Әптелбәр мич башында, каба агачына атланып, кулларын, аякларын тырпайткан, күзләрен йомган хәлдә: — Юл бирегез! — дип кычкыра --- иде.* Ә. Фәйзи.

Каба төбе — 1) тәрәшне яки йонны бәйләү өчен булган җайланманы беркетә торган такта. *Табынны җыеп, Хәлимне йокларга салгач, Фатыйма, каба төбенә утырып, җеп эрләргә тотынды.* И. Гази; 2) сүсне эрләгәннән соң каба тарагында калган чүбек.

КАБАК I *и.* 1. Сабаклары җиргә ятып үрмәләп үсә торган, шар сыман яки озынча зур җимешле яшелчә үсемлеге; җимешенең итчел өлеше һәм эфир маена бай орлыгы азык итеп файдаланыла. *Кыяр түтәлләрен әйләндергән куе кабак яфраклары арасыннан, атылып, Ибрай үзе килеп чыкты.* М. Әмир.

2. Шул үсемлекнең азык өчен кулланыла торган җимеше. *Кабаклары бик уңганнар: чүлмәк-чүлмәк булып тәгәрәшеп яталар.* Ф. Хөсни.

◇ **Кабак баш** — аңгыра, миңгерәү кеше. **Кабак булу** (баш турында) — берәр нинди сәбәп аркасында баш миңгерәп китү, аңламас дәрәҗәгә килү. [*Хәйри:*] *Минем башым кабак булды инде!* Г. Ибраһимов. **Кабак бәлеше** — җебегән, йомшак кеше. [*Локман Нәгыйлгә:*] *Ай, изрәгән кабак бәлеше!* Ш. Камал.

КАБАК II *и.* Күз алмасын алгы яктан каплап тора торган ике тире җыерчасы. *Солтан, курка төшеп, Зиннурның җыерчыклы кабаклары арасында хәйләкәр ялтыраган соры күзләренә карады.* А. Расих. *Кинәт Лида башын күтәрде, күп елаудан кабаклары шешенгән күзләрен Мухинга текәде...* Ә. Айдар.

Кабак җыеру — *к.* каш җыеру. — *Әгәр дога тозсыз чыксa, кабагыңны җыерма.* Ш. Бабич.

КАБАК III *и. иск.* Революциягә кадәр: исерткеч эчемлекләр сату һәм эчү өчен бик гади җиһазлы махсус бина. [*Нигъмәтҗан*] *эш булмаса, кабак алдына барып, тамчылап, сораныp эчте.* Ә. Фәйзи.

КАБАКЛАНУ *ф.* Кабакның чәчәге коелып, аның урынына яшел җимшән барлыкка килү. *Быел кабаклар иртә кабакланды.*

КАБАКЧЫ *и. иск.* Кабак (III) тотучы. | *с. мәгъ. Кабак янында беркем юк, Кабакчы хатын белән Ялгыз калды тик тал гына, Тибрәнеп акрын гына.* М. Җәлил.

КАБАЛА *и. тар.* 1. XIV—XVII йөзләрдә Мәскәү Русенда бурычларны, ясакларны түли алмауга бәйләнгән гомерлек крепостнойлык хәле; коллыкның бер төре.

2. *күч.* Тулысынча бәйле булу, колларча бәйлелек. *Хезмәт иясе крестьяннар эксплуататор кулаклар кабаласыннан тәмам һәм мәңгегә азат ителде.* СССР тарихы. *„Йолдыз“ кабаласыннан ычкынгач, ---* [*Г. Камал*] *үзенең публицистика телен дә художество әсәрләре теле дәрәҗәсендә итеп сафландыра.* М. Гали.

Кабалага керү (төшү) *күч.* — мөстәкыйльлеген югалту, кемгә дә булса бәйле булу, буйсыну. **Кабаладан чыгу** — бәйлелектән котылу, азат булу.

КАБАЛАЛЫ *с.* Кабалага нигезләнгән, кабалага бәйле. [*Крестьяннар*] *җирне алпавыттан кабалалы шартларда арендага алырга мәҗбүр булдылар.* Яңа тарих.

КАБАЛАН *рәв. диал.* Ашыгыч, ашыгыч рәвештә, тиз генә, җәһәт. *Тау башыннан пулеметлар чатырдатырга тотынгач, разведчик кабалан гына борылды да килгән ягына таба кире чаба башлады.* И. Гази. *Кайчан гына килеп карама, Директорның һаман вакыты юк, Аның эше һаман кабалан...* М. Җәлил.

КАБАЛАНУ *ф.* Бик ашыгып, тәртипсез хәрәкәт итү, ашыгып берәр нәрсә эшләү. *Ничек кенә булмасын,* [*хатын*] *бик ашыга, хәтта кабалана.* А. Шамов. || *рәв. мәгъ.* **кабаланып.** Ашыгып, кызуланып. *Сәлим каланчадан кабаланып төште дә ашыга-ашыга тар сукмак буйлап борчакка таба китте.* Г. Гобәй. *Ашыгып, кабаланып сөйләде-сөйләде дә, үзе сизмәстән, иртәнге сүзен кабатлап куйды* [*Гыймади*]. Г. Ибраһимов.

КАБАЛАП *рәв. диал.* Ярсып, үрсәләнеп. [*Эт*] *яшел киемле бу ят кешегә* [*Солтанга*] *кабалап өреп барды да, аның тавышын ишетүгә, --- чирәмгә ятып, койрыгын болгый-болгый үрмәли башлады.* Г. Бәширов.

КАБАЛАУ *ф. диал.* Кармалау, капшау. *Мескен ябалак, ботакларны кабалап-кабалап, башка агачка күчкән.* А. Алиш. [*Мәдинә*] *бармагына кигән йөзеген кабалап карады.* Ш. Хөсәенов.

КАБАН: кабан дуңгызы — сазлыкларда, камышлыкларда яши торган кыргый дуңгыз. *Алда бүреләр улаган, кабан дуңгызлары мыркылдаган бик яман тавышлар ишетелә башлады.* М. Гали. *Урман күселыгында алар җитез боланнар, пошилар, кабан дуңгызлары --- очраттылар.* А. Расих.

Кабан теш — башка тешләрдән өскә калкыбрак торган казык теш.

КАБАР: кабар агачы — составында гуттаперча матдәсе булган куак; *русчасы:* бересклет.

КАБАРГА *и. зоол.* Боланнар семьялыгыннан тауларда яши торган мөгезсез хайван. *Таулы районнарда изюбр, төньяк кыргый боланы, тау кәҗәсе, кабарга яши.* СССРның физ. геогр.

КАБАРДИН *и.* Кабарда-Балкар АССРда яшәүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Кабардиннарның җыр һәм бию ансамбле концерт программасын башлаганда, без дә кечкенә мәҗлесебезнең башлап җибәрдек.* Г. Мөхәммәтшин.

КАБАРДИ'НКА *и.* Кабардин биюе.

КАБАРЕ' *и.* Буржуаз илләрдә эстрадалы, зур булмаган кафе яки ресторан. *Парижның зур кварталларыннан мәшһүр Монмартрга кич барыгыз, сез анда бөтен дөньяга мәшһүр кабареларны, концерт залларын күрерсез.* Г. Гали.

КАБАРЛЫК *с.* 1. Авызга алырлык, ашарлык. *Дөрес, ашый башлагач, камыры авызга кабарлык пәрәмәчләрнең ите пешми калуы --- беркадәр уңайсызлык тудырды.* Ш. Хөсәенов.

2. *к.* кабым. [*Карт:*] *Кызым, авылыгызда, өй буенча йөреп, бер кабарлык икмәк тә таба алмаган идем, тик син генә бирдең.* М. Гали.

КАБАРТМА *и. махс.* Ачы камырдан вак-вак итеп түгәрәк формада ясалып, майлы табада мич алдында яки плитада пешерелә торган ашамлык. [*Хәдичә түти*], *--- акрын гына кыштырдый-кыштырдый, кабартмасын әвәләде, мичкә ягып җибәрде.* Г. Бәширов. [*Карчык*] *бер ялгызы гына мичтән яңа --- чыккан бодай кабартмасы белән чәйләп утыра иде.* Г. Гобәй.

◇ **Кабартма бит** — кабарып торган тулы, симез бит. *Күрше бүлмәдән башына чуклы кызыл фәс кигән кабартма битле бер зуррак малай килеп чыкты.* И. Гази.

КАБАРТУ *ф.* 1. Бүлтәйтү, бүлтәйтеп чыгару. [*Гыйният:*] *Яңадан көзге алдына барып, ике кулын бөгеп көчле мускулларын кабарта.* А. Әхмәт.

2. Берәр сәбәп аркасында аякларда, кулларда куык, кабарчык барлыкка китерү. *Ташлы юлдан бару аякларны кабартты.* М. Гафури.

3. Басылган, изелгән нәрсәләрне (мендәр, түшәк, печән һ. б.) күпертү. *Гөлнур, чаршау артында түшәк кабартып түшәгәч, икенче бүлмәгә чыкты.* К. Нәжми. *Авыррак иде әле* [*Гөлзифага*] *печән кабартуда өлкән апалардан калышмыйча өлгереп баруы.* Р. Төхфәтуллин. || Казып йомшарту. *Хәтта әле бер урында Гайҗан агай башын да селкеп куйды: янәсе, кабартканнар да соң җирне, рәхмәт төшкерләре.* Ф. Хөсни.

4. Камырны басканнан соң яки ясап бетергәч, мичкә куяр алдыннан бераз вакыт җылыда тотып күтәртү. || Сөтне яки токмач салган ашны тиз генә кайнатып чыгару.— *Токмачыңны тизрәк кабартып чыгар! Ишетәсеңме, килен?* С. Рафиков.

5. Мамык, йоннарны һ. б. тырпайту, күтәрү (кошлар, хайваннар һ. б. турында). [*Акбүз*] *сыртын, йоннарын кабартты.* Г. Гобәй. *Күз алдымда кызыл канатларын кабарткан, авызын ачкан алабуга торса да, сүзем икенче булды.* А. Әхмәт.

6. Туп, шин һ. б. ш. кебекләрне һава, газ белән тутырып тыгызлау, күләм ягыннан зурайту. [*Зиннәт абзый*] *машина насосы белән өреп кабарткан резина капчыкка шаккатып карап торды.* Г. Ахунов. || Киерү (җилнең җилкәнне, киемне һ. б.).

7. *күч.* Нинди дә булса хәл яки хәбәрне арттырып сөйләү. *Усал телләр* [*гайбәтне*] *тагы киңәйтеп, кабартып сөйли башладылар.* Г. Ибраһимов. [*Гомәр:*] *Гыймади абзый, --- колхозыбыздагы кыенлыкларны яман кабартып күрсәтергә ярата башладың әле син.* И. Гази.

Кабарткан паштет *махс.*— гадәттәгегә караганда йомырка һәм шикәр комы күбрәк салынган камырдан пешерелгән паштет. [*Гарифә:*] *Таҗиләргә чәйгә барган идем, кабарткан паштетлары менә нәкъ такта шикелле булган.* Г. Камал.

КАБАРУ *ф.* 1. Бүлтәеп чыгу, бүлтәеп, чыгынкыланып тору. *Яңак буйларында калкулы чандырлар кабарып чыкты.* Ш. Камал.

2. Шешеп чыгу, шешенү. *Стена буендагы агач диванда Фәрит утыра, борыны зураеп киткән, кабарган иреннәре кырыенда кан эзе.* Р. Төхфәтуллин. || Нинди дә булса сәбәп аркасында тәннең берәр урынында куык яки кабарчык барлыкка килү. *Биек таштауларда, калын баткак урманнарда йөреп, минем аякларым кабарды, суелды.* М. Максуд. *Әтисе --- кабарып беткән зур кулы белән Газинурның җиткән чәченнән сыйпады һәм һаман бер үк сүзләрне кабатлады.* Г. Әпсәләмов.

3. Күтәрелү, күперү (камыр һ. б. турында). [*Гөлниса:*] *Килен, камырың кабарган.* Т. Гыйззәт. || Һава тулып өрелү. *Җәмиләнең зәңгәр күлмәге җилләр искән саен кабара.* М. Җәлил. || Кайнап чыгу, күбекләнеп күтәрелү (сөт, аш һ. б. турында). — *Казанда сөтем кайный калган иде, кабарып түгелә торгандыр,— диде* [*Миңниса*]. С. Рафиков. *Әнием --- өйгә керү белән алдыма яңа гына кабарып чыккан токмачлы шулпа белән икмәк китереп куйды.* Г. Галиев.

4. Күтәрелү, күперү, тырпаю (йон, мамык, чәч һ. б.). *Тик башында бүрек сыман йоннары кабарып торган тау чыпчыклары гына чыркылдашып бу тынлыкны бозалар.* Ә. Айдар. *Актырнакның тешләре ыржайды, йоннары кабарды.* И. Гази.

5. *күч.* Үзен эре тоту, зурга кую, масаю, һавалану, мактану.— *Син* [*Галиә*] *аз гына байлык белән кабарып йөрүче вәждансыз нәрсә түгелме соң?* М. Гафури.

6. *күч.* Арту, киңәю, үсү (нинди дә булса хәл яки хәбәр турында). *Башта шулай Кадыйр бай приказчиклары белән „Мәдрәсәи исламия“ шәкертләре тирәсендә кайнаган бу сүзләр* [*төрле хәбәрләр*] *тиз арада бик тиз җәелеп тә киттеләр, үстеләр, кабардылар.* Г. Ибраһимов.

7. *күч.* Симерү, юанаю. *Ни өчен берәүләр корсак киерәләр, кабаралар?* Г. Тукай.

8. *күч.* Ачулану, ярсу. *Д басуда һәр коелган бөртек* [*директорга*] *йөз мең тамчы төсле кыйбат тоела, ул шуларга пошына, кабара.* М. Җәлил. *Бөтен барлыгын яулап, кабара барган ачуын баса алырлык хәлдә түгел иде* [*Варис*]. М. Хәсәнов. || Күп уйланудан, төрле тойгылар тәэсире белән уйлый, эшли алмас дәрәҗәгә җитү (баш, ми һ. б. турында). *Урмановның теленә бер сүз килә, ачудан миң кабарып, әйтергә хәленнән килми.* Г. Ибраһимов.

КАБАРЧЫК *и.* Берәр сәбәп аркасында тиредә барлыкка килә торган сулы куык; авыртулы шеш, төер. || Су яки башка төрле масса эчендә барлыкка килгән һава, газ куыгы.

КАБАРЫНКЫ *с.* 1. Кабарып торган; күпереп торган. [*Печәнчеләр*] *артыннан кабарынкы яшел печән өемнәре тасмадай сузылып кала бара.* З. Бәширн. *Салкынга күшегеп, ахры, тавыклар кабарынкы күренәләр.* С. Рафиков. *Ак читле кабарынкы болытлар язгыча бик биектән ашыгып агалар.* Ә. Еники.

2. *махс.* Өслеге тышкы якка таба калкып чыгып торган. *Кабарынкы линза.* □ *Телескоптагы кабарынкы пыялалар ерактагы күк җисемнәрен гүя безгә якын китерәләр.* Үтк. зам. сәяхәт.

3. *күч.* Күперенке (стиль, сүз һ. б.). *Кабарынкы сүзләрдән генә торган бу символистик парчаларны*

[*соңгы икесен*] *элеккерәк бер җыентыгымда хәтта бастырып та чыгардым кебек.* Ф. Хөсни.

Кабарынкы күппочмак *мат.*— күппочмакның теләсә кайсы ягын чиксез дәвам иттергәндә бу турының бер ягында калган күппочмак.

КАБАРЫНКЫ-БАТЫНКЫ *с.* Бер ягы кабарып, икенче ягы батып торган. *Кабарынкы-батынкы линза.*

КАБАРЫНКЫЛАНУ *ф.* Кабарынкы булып тору, кабарынкыга әйләнү.

КАБАРЫНКЫЛЫК *и.* Кабарынкы булу сыйфаты. *Җир өстенең кабарынкылыгы бүтән күзәтүләр белән дә раслана.* Физ. геогр.

КАБАРЫНУ *ф.* 1. *Кайт. юн. к.* кабару 4. *Бакча буенда, төрле якка сибелгән чебиләрне җыя алмыйча, кабарынган чуар тавык курылдап йори.* Г. Бәширов.

2. Үзен эре тоту, масаю. *Җәләл ни дияргә белми, --- күзләре дә --- мактанып карыйлар, бөтен торышында бер кабарыну әсәре күренә.* Г. Ибраһимов.

3. Ачулану, ярсу; тузыну. *Соңгы вакытта Искәндәр, --- бер сүз әйтер хәл юк, хәзер кабарынып, тузгып китәргә тора.* М. Галәү. *Безнең күке бу эшкә бик нык ачуланды, кабарынды.* Г. Тукай.

КАБАТ *рәв.* Яңадан, тагын; икенче кат, икенче тапкыр, икенче мәртәбә. *Кабат килмә дисең кебек син; Сизәсеңме үзең, юктырмы.* З. Мансур. [*Әби*] *солдатларны кабат яралану куркынычыннан, ә бәлки үлемнән коткара.* Г. Гобәй.

Кабат җитештерү — даими яңарып, үзлексез кабатланып тора торган иҗтимагый җитештерү процессы. *Җитештерү шартлары нинди булса, кабат җитештерү шартлары да шундый була.* Политэкономия.

КАБАТ-КАБАТ *рәв.* 1. Кат-кат, берничә тапкыр (эшләү). *Авыр минутларында* [*Фатыйма*] *йөзен мендәренә каплап үкседе, --- Фәритнең фронттан язган „өчпочмакларын" кабат-кабат укыды.* Г. Минский.

2. Өсте-өстенә, кат-кат. *Лукьянның өстендәге чикмән чынлап та иске капчык, чолгау кисәкләре белән кабат-кабат ямалып, чуарланып беткән.* Ш. Камал.

КАБАТЛАНМА(ЛЫ) *с.* Кабатлана торган, һаман-һаман кабатлана торган.

КАБАТЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* кабатлау (1—3,5 мәгъ.). *Вакыйга тагын кабатланып сөйләнә башлады.* М. Гафури. *Вәли тәҗрибәле эшчеләргә хас җай белән эшли, кабатланмый.* Г. Әпсәләмов.

2. Яңадан, кабат булу, күренү, ишетелү (нинди дә булса эш-хәл, күренеш, тавыш һ. б. турында). *Һава тревогасы бу шәһәрдә еш кабатланып торды.* Г. Гобәй. *Теге йомшак җавап тагын кабатланды.* Ф. Хөсни.

3. Яңартылу, кичерелү; яңадан барлыкка китерелү. *Кабатланды яшәвендә аның һәр сүзенең кайнар сулышы.* Ш. Маннур. *Нәфисә хәзер Зиннәт белән ике арадагы кебек ялкынлы, тирән мәхәббәтнең яңадан кабатлануына ышанмый иде инде.* Г. Бәширов.

4. Кайтаваз ясалу. [*Металлның*] *тавышы Урман, тауларда Кабатланып каршы алына.* Ф. Кәрим.

5. Тапкырлану, арту. *Һәрбер пуля безнең йөрәкләрдә Көрәш дәрте булып кабынды. Шул дәрт белән унга, егермегә Кабатланып үсте колонна.* М. Җәлил.

КАБАТЛАНУЧАН *с.* 1. Еш кабатлана, еш очрый торган.

2. Бер үк нәрсәне берничә тапкыр кабатларга яратучы (мәсәлән, доклад сөйләгәндә).

КАБАТЛАНЫШ *и.* Кабатлану. *Авазлар кабатланышы.*

КАБАТЛАП *рәв.* Кабат, икенче тапкыр, яңадан.

КАБАТЛАУ *ф.* 1. Бер эшне нәкъ шул рәвештә икенче тапкыр башкару.—*Бары егерме тәүлек эчендә мин Архангельскидан Владивостокта булырга, „Сибиряков" үткән юлны кабатлап карарга, хөкүмәт куйган бурычны үтәп чыгарга тиешмен,— диде зур галим.* А. Алиш. *Узгандагы хаталарыңны хөкем итә белмәсәң, аларны яңадан кабатлавың мөмкин.* А. Гыйләҗев.

2. Икенче берәүнең эш-хәрәкәтен аныңча эшләү. *Марат исә --- үзенчә сөйләнеп, сестра нишләсә, шуны кабатлап йөри бирде.* Г. Гобәй. || Икенче берәүнең сүзләрен аныңча үк итеп әйтү. [*Василий:*] *Бөтен сорауларга җавапны үзем бирәм, ә сез мин әйткәнне кабатлап кына торырсыз.* Ә. Еники.

3. Бер үк нәрсәне берничә мәртәбә эшләү, әйтү. *Әхмәдулла, җавап көтеп, соравын кабатлады.* А. Шамов. || Бер нәрсә турында кайта-кайта сөйләү. *— Әйдә, Габделхәй, ләкин кабатлама, кыска тот.* Ш. Камал.

4. Яңадан ишеттерү, кире кайтару (мәсәлән, тагыш, кайтаваз, яңгыраш турында). [*Балыкчылар*] *җырламаган, җырлагандай ыңгырашканнар, Каспий ярлары Кабатлаган әрнеп ыңгырашуның Скаладан кайтып яңгыравын.* М. Җәлил.

5. Элек өйрәнелгән нәрсәне яңадан укып хәтердә яңарту, искә төшерү, яңадан әйтү. *Грамматиканы кабатлау.* □ [*Ибрай:*] *Менә бу теореманы онытам, --- башта шуны кабатлыйк әле, Каюм.* Г. Гобәй.

6. *к.* тапкырлау. *Бер әйләнү 15 минут, төрән алымы бер метр, йөрү икенче тизлектә. Шуннан кабатлап чыгаргач, син сменаңда --- утыз дүрт әйләнеш ясарга тиешсең.* Ф. Хөсни.

7. *әд.* Бердәй авазларның яки сүзләрнең билгеле бер эзлеклелектә килүенә нигезләнгән шигъри алым. *Кабатлау, каршы кую характерындагы синтаксик фигуралар куллану шигырь ритмына җанлылык --- кертә.* Г. Нигъмәти.

КАБАТЛАУЛЫ: кабатлаулы фигыль *лингв.*— эш яки хәлнең кабатлануын яки сирәгрәк булуын аңлата торган фигыль (мәсәлән, **баргалау, килгәләү**).

КАБАТЛЫ I *с. сөйл.* Катлы. *Ике кабатлы калын иреннәрен каплап, бөтен көче белән чын-җитди күренергә тырышкан чагында да* [*Садрыйның күзләрендә*] *кешене мыскыллау --- күренә иде.* Ш. Камал.

КАБАТЛЫ II *с.* Нинди дә булса санга калдыксыз бүленә торган. *Кабатлы саннар.* || *и. мәгъ.* Калдыксыз бүленә торган бөтен сан. *Бирелгән саннарның кабатлысы.*

КАБАТТАН *рәв.* Яңадан, тагын. [*Газинур*] *инде фашистларны җиңмичә торып колхоздагы матур тормышның кире кайтмавын да, хатынын, бала-чагаларын кабаттан күрә алмавын да аңлый иде.* Г. Әпсәләмов.

КАБАХӘТ *с.* 1. Әшәке, пычрак, жирәнү тудыра торган (әйбер, урын һ. б. турында). *Мондагы эш* [*шартлары*] *башка рудникларга караганда да кабахәтрәк икәне күренеп тора.* Ш. Камал. | Эш, хәрәкәт, тәртип һ. б. турында. *Капка аша гына торучы --- бер карчык --- гайбәткә тагы да кабахәтрәк төс бирде.* Г. Гобәй.

2. Тупаслыгы, әдәпсезлеге белән жирәнү хисе уятырдай. *Шулкадәр кабахәт булып күренде миңа ул кеше.* М. Әмир. || *и. мәгъ. сөйл.* Сүгенү сүзе буларак кулланыла. [*Егет немец офицерына:*] *Кабахәт! Миннән бер сүз дә ала алмассың! — диде.* А. Шамов.

3. Әдәпсез, әшәке (сүзләр турында). *Мин сиңа, мелла Закир, мондый кабахәт сүзләр сөйләшеп утырырга килмәдем.* Ф. Әмирхан.

КАБАХӘТЛЕК *и.* Кабахәт эш; явызлык, эшәкелек, начарлык. *Ник саныйм гайбен аның соң? Мин түгел бухгалтеры! Ул кабахәтлектә миллиардер танылган Мостафа.* Г. Тукай. [*Фәтхерахман*] *Мөгълифә карчык кебек, акча өчен дөньядагы һәрбер кабахәтлекне*

әшләүдән тартына торган кеше түгел. М. Гали. || Кабахәт кешегә хас сыйфатлар.

КАБАХӘТЛӘНҮ *ф.* Бозылу, әшәкеләнү, намуссызлану. — *Син [Закир] тәмам кабахәтләнүнең ниһаятенә җиткән икәнсең инде.* Ф. Әмирхан.

КА'БЕЛЬ *и. тех.* Электр энергиясен тапшыру, сигнализация һәм элемтә урнаштыру өчен тышкы тәэсирләрдән саклый торган герметик тышчалы бер яки берничә җепле тимер чыбык. *Телефон кабеле.* □ — *Элемтә өзелде. Сиваш пычрагы кабельне ашый икән,— диде телефонист.* Г. Бәширов.

КА'БЕЛЬТОВ *и. махс.* 1. Диңгездә 185,2 *м* озынлыгындагы үлчәү берәмлеге. *Босфор бугазының озынлыгы уналты миль, тарлыгы дүрт кабельтовка җитә.* Каз. утл.

2. 150 *мм* дан 300 *мм* га кадәр юанлыкта, киндер сүсеннән ишелгән, суднода кулланыла торган трос.

КА'БЕЛЬЧЕ *и. махс.* Кабель ясау яки кабель үткәрү белән шөгыльләнүче эшче.

КАБЕР *и.* 1. Үлгән кешене күмәр өчен казылган махсус чокыр. *Икенче көнне төнлә белән карт бакчада --- кабер казыды, һәм алар очучы егетне шунда хөрмәтләп күмделәр.* А. Шамов. || Үлек күмелгән урын. *Каберемне кочып еласам да, Калды мәңге әрнеп йөргәм.* Ш. Маннур.

2. *күч.* Үлем. [*Авылга*] *барып, мужик арасында кабер эзләр хәлем юк,— диде* [*карчык*]. Г. Ибраһимов.

3. Кысан, тар урын, бина һ. б. *Беренче тапкыр төрмәнең калын дивараларын, --- караңгы, кысан, тынчу камераларын күргәч, Назимов монда кабер --- дип уйлаган иде.* Г. Әпсәләмов. [*Имәли—карчыгына:*] *Өй түгел иде бит ул, кабер иде.* М. Әмир.

Кабер казучы — 1) зиратта кабер казып торучы кеше. *Кабер казучыларга түләргә эш рәтләнде.* Ш. Камал; 2) *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса үлем, һәлакәт алып килүче. *Кулаклар бу егерме йортлы колхозда үзләренең кабер казучыларын күрәләр.* Г. Толымбай. **Кабер сәдакасы** *иск. дини.— к.* гүр сәдакасы. *Тавык белән күмәч кабер сәдакасы итеп мәзингә бирергә ул!* Ш. Камал.

◇ **Кабер алу** — үлү. *Анамны хәтәрли алмыйм: минем гомерем яшь ярымга җитмәстән әлек, аны кабер алган.* Г. Ибраһимов. **Кабер газабы** *иск.*— газаплы, бик авыр тормыш. [*Әхмәт:*] *Бу ямьсез дөньядан, бу кабер газабыннан котылыр идем.* Г. Камал. — *Ай тулу, фатир акчасы табу — минем өчен кабер газабы.* Ш. Әхмәдиев. **Кабер казу** — кемгә яки нәрсәгә дә булса һәлакәт алып килү, үлем хәзерләү. *Килгән алар ерак Испаниядән Азатлыкны саклап калырга һәм Пиреней ярымутравында Фашизмга кабер казырга.* Ә. Исхак. **Кабер табу** — һәлак булу, үлү, юкка чыгу. *Бик күп галимнәр [төньякта] үзләренә кабер таптылар.* А. Алиш. **Кабер тынлыгы** — тулы тынлык (гадәттә шомлы булып тоелган). *Берничә минутка блиндажның эче кабер тынлыгына чумды.* К. Тинчурин. **Кабер якасында булу** — үләр хәлгә җиткән, артык карт булу. *Ватан сугышы башланганда [Шәйхаттар бабай] инде, --- үз сүзләре белән әйтсәк, кабер якасында була.* Г. Гобәй. **Кабер якасына килү (җитү, басу)** — үләргә вакыт җитү (бик карт һәм өметсез авыру кешеләр турында).— *Әнә, кабер якасына баскан карчык белән үзгәз сөйләшеп карагыз.* Ф. Хөсни. **Кабердән чыккан төсле (кебек)** — артык ябык, ак чырайлы, хәлсез (кеше турында). [*Зыя*], *электән ябык булса да, бу чаклы түгел иде; әле кабердән чыккан кеше төсле булган.* Г. Ибраһимов. **Каберең ерак булсын, каберең якын (янәшә) булмасын** — явыз, начар кешеләр белән бәйләнеш тоту кирәк түгеллеген искәртеп әйтелә. *Йомышың төшмәсен шул Биктаһирныкыларга, каберең янәшә булмасын, кәфенеңне таларлар.* И. Гази. *Мәликә белән каберең якын була күрмәсен.* А. Шамов.

КАБЕРЛЕК *и.* Үлекләр күмү өчен махсус билгеләнгән урын, зират. *Каберлекнең түбән бер почмагында өсте үләнсез яңарак кабер бар иде.* Ш. Камал.

КАБЕРНЕ' *и.* 1. Виноградның куе зәңгәр төстәге төре (кызыл аракы ясау өчен файдаланыла).

2. Шул виноградтан ясалган кызыл аракы.

КАБЕРСТАН *и. иск. к.* каберлек. *Ригада булып та аның Туганнар каберстанын күрми киткән кеше — Риганы күрми киткән кеше ул.* Г. Әпсәләмов.

КАБЕСТАН *и. махс.* Йөкләрне бер урыннан икенче урынга күтәреп күчерү өчен кулланыла торган лебедка.

КАБЕРЧЕ *и.* 1. Кабер казучы.

2. *күч. к.* кабер казучы 2. *Капитализм үз эчендә үзенең кабәрчесен үстерә, вакыт-вакыт җиңелсә дә, бу куәт үлми.* Г. Ибраһимов.

КАБЗЫЯТЬ *и. иск. кит.* Куркып калу, каушау. *Аллә нишләп мине кабзыять алып тора.* Ш. Камал.

КАБЗЫЯТЬЛЕ *с.* Каушаулы. *Җәгъфәр --- кабзыятьле тавыш илә --- сөйли башлады.* Г. Тукай.

КАБИЛ *и. иск. кит.* (гадәттә тартым һәм кыек килеш форм.) төр, төркем. *Дүвәлге ике юл анчак скрипка уйнаганда бер кәррә кыл тартып кую кабиленнән генә бер нәрсәдер.* Г. Тукай. *Ат дәрте [Җәләлдә] шифасы булмаган бер авыру кабиленнән.* Г. Нигъмәти.

КА'БИЛИЯТ *и. иск. кит.* Сәләтлелек, булдыклылык, кулдан килү. *Мәдрәсәдә йөзләгән шәкерт арасыннан сарыф-нәхү укучылар, аны укырга кабилияте булучылар аз чыга.* М. Гафури.

КА'БИЛИЯТЛЕ *с. иск.* Сәләтле, булдыклы.— *Хәмит кабилиятле, ул булдырыр...* К. Тинчурин.

КА'БИЛИЯТЛЕЛЕК *и. иск.* Сәләтле булу, булдыклы булу, талантлы булу.

КАБИЛӘ *и.* 1. Үзара кардәшлек мөнәсәбәте, уртак тел һәм гореф-гадәт белән бәйләнгән, бер үк җирдә яшәүче кешеләр төркеме. [*Мохтаҗлык*] *кешеләрне зур-зур кабиләләр булып торырга мәҗбүр итә.* Г. Тукай. || *с. мәгъ.* Кабиләгә мөнәсәбәтле. *Кабилә теле.* □ *Байның үзе торган өлкән өйгә илнең зурлары, кабилә башлыклары, аксакаллары, биләре, байлары утырдылар.* Г. Ибраһимов.

2. *иск.* Халык. *Төрки кабиләләр.*

3. *иск.* Парлы сүз составында: ыру, ерак туганнар. *Дус-ишләребез, кардәш-кабиләләребез илә күрешергә вә йөрешергә дә вакытыбыз булмый.* Г. Тукай.

КАБИЛӘДӘШ *с.* Бер кабиләдән булган. *Кабиләдәш халыклар.*

КАБИЛӘЧЕЛЕК *с. тар.* Кабилә булып яшәүгә бәйләнгән. *Кабиләчелек тормышы. Кабиләчелек дошманлыклары.* □ [*Г. Ибраһимов хикәяләрендә*] *кабиләчелек талашлары, җәйләүләре, кымызлары, калымнары, --- безнең өчен яңа, ят булган экзотикалары белән күз алдына бастырылган казакъ хәяты да бар.* Г. Нигъмәти.

КАБИ'НА *и.* Билгеле бер максат өчен кечерәк кенә, махсус җиһазландырылган аерым бүлмә, бүлем. *Сайлау кабинасы.* □ *Нәкъ көнчыгышка карап очкан самолет кабинасының тәрәзәсендә кояшның беренче нурлары уйнады.* Г. Гобәй.

КАБИНЕТ *и.* 1. Махсус эш бүлмәсе (өйдә, учреждениедә).— *Эш турында сөйләшү өчен булса, заводка, минем кабинетка килегез, Гайсин иптәш.* Р. Ишморат.

2. Уку йортларында, фәнни-тикшеренү, дәвалау учреждениеләрендә һ. б. урыннарда приборлар, коллекцияләр һ. б. белән җиһазландырылган махсус бина, бүлмә. *Физика кабинеты. Рентген кабинеты.* □ *Каюм, акчаларны күрүгә, дөньясын онытты. „Тарих кабинетына экспонат менә кайда ул!*

1700 елда сугылган!" Г. Гобәй. *Докторның кабинетында авыруларны кабул итү бара.* һ. Такташ.

3. Ресторанларда, күнел ачу бакчаларында аерым бүлем, бүлмә. [*Официант:*] *Исәнмесез, менә монда рәхим итегез, бик шәп кабинет, үзе яхшы, үзе аулак.* Г. Камал.

4. *полит.* Кайбер илләрдә хөкүмәт тәшкил итүче министрлар составы; хөкүмәт. *Кабинет алмашыну. Министрлар кабинеты.* || Россиядә XVIII һәм XIX йөз башында патша сараенда хуҗалык һәм финанс эшләрен алып бара торган бер бүлек.

КАБИНКА *и. сөйл. к.* кабина. *Кояш нурларында [автомобильнең] фаралары, кабинка пыяласы ялтырап китте һәм бер генә секундка Газинурның күзләрен чагылдырды.* Г. Әпсәләмов.

КАБИХ *с. иск. к.* кабахәт. *Берәүгә матур күренгән нәрсәнең икенчегә ямьсез, кабих булып күренүе кешеләрнең иҗтимагый тормышлары төрлелегенә карап йөри.* Г. Нигъмәти. *Иблис --- бер кабих эш кылды.* Ш. Бабич.

КАБЛОГРА'ММА *с. махс.* Су асты кабеле буенча тапшырыла торган телеграмма.

КАБОТАЖ *и. махс.* **1.** Бер үк ил яки бер үк диңгез ярлары буендагы портлар арасында йөзү. *Чит илгә йөзүчеләр белән чагыштырганда каботаж диңгезчеләренең киемнәре дә башка төрлерәк иде.* М. Юныс.

2. Диңгез яры буенда гына йөри торган судно.

КАБОТАЖЧЫ *и. махс.* Каботажда эшләүче диңгезче.

КАБРИОЛЕТ, КАБРИОЛЕ'ТКА *и.* **1.** Бер ат кына җигелә торган биек күчәрле, ике тәгәрмәчле җиңел арба.

2. *махс.* Җиңел автомобильдә өсте һәм яннары ачыла торган кузов.

КАБУ *ф.* **1.** Ашау яки эчү өчен авызга алу. *Ул өстәл янына утыра. Берничә кашык аш каба да туктамыйча кала.* Р. Ишморат. || Ашап, эчеп алу. — *Я, куй әле, кияү,— дип шып туктатты аны җизни кеше,— бала булса да,* [*Габдулла*] *мосафир кеше бит, ял итсен, тамагына капсын!* Ә. Фәйзи. || Эчү, йоту (даруны). — *Берәр капсуль хин кабып җибәрсәң, хәзер [башың] төзәлеп китәр.* Г. Камал. || *күч.* Исерткеч эчемлек эчү. *Бабай кыстатмады:* — *Күптән капкан юк бит, нишләргә икән?* — *дип, [аракының] сафлыгын карады.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр нәрсәне иреннәргә кыстыру. *Малайлар, камыш төбенә чумып, авызларына куыш эчле камыш кабып яталар.* Г. Гобәй. *Сәлим, кесәсеннән көмеш тәмәке савыты чыгарып, авызына папирос капты.* Г. Әпсәләмов.

3. Тешләү (әт турында). *Усал әт арттан килеп өрми кабар.* Мәкаль.

4. Эләгү, чиртү (балык турында). *Кояш чыгып бераз күтәрелгәч --- шыртлака кабып аптыратты.* А. Гыйләҗев.

5. Нык тәэсир итеп авырттыру (эссе, начар һава, көчле тавыш һ. б.). *Башка каба эфир, кан исе, дөтә алмый сабый сүзләрен.* Ф. Кәрим. *Башка кызу капкан иде.* М. Максуд.

6. *күч.* Эләгү, тотылу. *„Каптым" дип уйлады ул һәм изелеп төште, тик шунда ук үзен кулга алып, күз ачып йомганчы дошманына ташланды.* Г. Гобәй. *Үземнең мавыгыбрак китүемне хәзер генә, немец засадасының тозагына килеп капканнан соң гына сизендем.* Ф. Хөсни.

7. Кысылу, каплану (сулыш). *Сулуы кабып беткән Галиулла, кәҗәнең мөгезеннән тотып алгач, усал итеп пышылдады.* И. Гази.

◇ **Кабар ризыгы бетү** — кешенең яшәү вакыты бетү. *Кешенең кабар ризыгы бетмәгән булса, Гандәлип туты, ис итмәгәндә килә дә чыга бит.* Ш. Камал. **Кабар урыным (җирем) калмады** — бик нык тую, яңадан әз генә дә ашыйсы килмәү.

КАБУЛ: кабул булу — тормышка ашу, үтәлү (каргыш, теләк һ. б. турында). *Бу эшкә [өйләнешүгә] атаң түгел, бөтен дөнья халкы бәддога кылса да, кабул булачак түгел.* Г. Коләхметов. *Сөйгәнеңне алсаң иде, теләгең кабул булып.* Җыр. **Кабул бүлмәсе** *иск.* — йомыш белән килүчеләрне кабул итү бүлмәсе. *Тартыша-тартыша торгач, ишанның кабул бүлмәсенең ишеге төбенә җитәргә мөвәффәкъ булдым.* М. Гафури. **Кабул итмәү (күрмәү)** — ошатмау, килештермәү, күнел тартмау. *Синнән башка бүтәннәрне Күңлем кабул күрмәйдер.* Г. Тукай. **Кабул итү** — 1) берәр кеше тарафыннан бирелгән әйберне (яки заказны) алу. [*Газиз:*] *Рәхмәт, Зәйнәп, ләкин хәзер бу бүләкне кабул да итмим.* Ф. Әмирхан; 2) тапшыручыдан алу (товар, әйбер). *Гыймади алар китергән алмаларны үлчәп, кабул итеп тора.* М. Җәлил; 3) эшләнеп беткәннән соң, файдалану өчен яраклы дип рәсми рәвештә тану. *Тәзкирә, --- тракторчылар эшләгән мәйданнарны кабул итеп алу өчен, кичен трактор бригадасына килде.* Ф. Хөсни; 4) кемнең дә булса белемен тикшереп, бәя кую. *Имтихан кабул итү;* 5) нәрсәне дә булса үз җитәкчелегеңә алу. *Взвод кабул итү. Уку өен кабул итү;* 6) үзенә алу, урын бирү, сыендыру, урнаштыру. [*Габдулланы*] *бай өйгә, тук һәм һәр яктан канәгать семья эченә кабул иттеләр.* Ә. Фәйзи. *Очкычларны кабул итәр өчен хәзерләнгән аэродромны кар күмеп китте.* А. Алиш; 7) сөйләшү, әңгәмә өчен керергә рөхсәт бирү. [*Госманга*] *фанера заводы кешесен кабул итәргә туры килде.* А. Шамов; 8) каршы алу, кунак итү. *Газизә абыстай Лизаны бик хөрмәтләп кабул итте.* Ф. Әмирхан; 9) авыруларны карау. *Ул көнне мин биш-алты авыру гына кабул иттем.* Н. Фәттах; 10) нинди дә булса оешма яки группа составына кертү; нәрсәгә дә булса катнашырга рөхсәт бирү. *Агымдагы эшләрдә партиягә кабул итүне сораган биш заявление каралды.* Ш. Камал. *Яңа кешене разведчиклар үз семьяларына бары тик сугышта сыналганнан соң гына кабул иттеләр.* Г. Әпсәләмов. || Сәхнәдә куяр өчен алу (пьеса, опера һ. б.). *Кимчелекләрне бетермичә, либреттоны тулысынча кабул итеп булмаячак.* М. Җәлил; 11) радио, телеграф, телефон буенча тапшырыла торган хәбәрләрне тыңлау, язып алу. *Авылга килгән телеграмманы башлап ул кабул итә бит.* Г. Минский; 12) сүз, эш һ. б. ны берәр ничек дип аңлау. *Кичә әйткән сүзләремне минем Кызык кына кабул иттең син.* З. Мансур. *Габдулла [Зөһрә апаның сукрануын] үз хисабына кабул итте.* Ә. Фәйзи; 13) берәр нәрсә белән килешү, ризалашу; дөрес дип табу. *Тәкъдимне кабул итү. Чакыруны кабул итү;* 14) тавышка куеп берәр нәрсә белән килешүне белдерү; раслау. *Резолюцияне Шихрай тавышка куйды, һәм җыелыш аны беравыздан кабул итте.* Ш. Камал. *Без танктан чыгарга һәм, автоматларыбыздан ут ачып, дошманга каршы сугышырга дигән карар кабул иттек.* Р. Ишморат; 15) берәр дингә күчү. *X гасыр ахырында Русь Византиядән христиан динен кабул иткән.* Урта гас. тарихы; 16) берәр төрле титулны, исемне үзенә алу. *Асиянең бер читтә мине көтеп торганын сизеп, бу ялган исемне [язучы исемен] иректсез кабул итәргә мәҗбүр булдым.* А. Шамов; 17) гадәт итеп алу, күнегү, ияләшү. *Менә мин шиблит киям, әмма ифрат китеп, эченнән оек та киеп йөрү кадәрлесен кабул итә алмыйм.* Ф. Әмирхан; 18) тудыру вакытында ярдәм күрсәтү. *Әле генә бала*

кабул итеп, яңа ел иртәсендә урам буйлап кайтып килүче әминәне авыл кешеләре туктаусыз котлыйлар. Соц. Тат. **Кабул кылу** *иск.* — *к.* кабул итү (6—8, 14 мәгъ.). [*Ушаковта*] *бик зурлап кабул кылып,* [*Җәләлгә*] *сый-хөрмәт күрсәткәннәр.* Г. Ибраһимов. **Кабул күрү** — 1) яхшы дип табу, риза булу. *Минем кайда икәнлекне сорамагыз, Җибәргәнне* [*акчаны*] *кабул күреп алыгыз.* Ф. Хөсни; 2) үз итү, якын күрү. *Тик Галимә апага очраган, аны кабул күргән кешеләр, --- бик сирәк очрый торган бер нәрсә күргән кебек карап үтәләр.* М. Гафури. **Кабулым юк** — ошатмау, яратмау, кабул итмәү турында. *Кыз күтәрелеп карамады, акрын эчке аваз белән җавап кайтарды: „Әйткәнем шул: минем аңа кабулым юк! Күңелем башкададыр!“* Г. Ибраһимов.

КАБЫГУ *ф. сир.* Озак ятып басылу, укмашу. || *күч.* Беркая да чыкмый яту. *Тыным тарыга минем монда! Ниндидер авыр ишекләр! Кабыккан кешеләр.* Н. Исәнбәт.

КАБЫЗГЫЧ *и.* Шартлаучан матдәләрне кабызып җибәрү өчен махсус патрон; *русчасы:* запал.

КАБЫЗУ *ф.* **1.** Яндыру, яндырып җибәрү. *Газинур тәмәке кабызды һәм дулкынланып тарта башлады.* Г. Әпсәләмов. *Госман* [*әнисенә*] *бер-ике йотым эчерде дә, примусын кабызып җибәреп, чәйнек белән су куйды.* А. Шамов.

2. Эшләтә башлау, хәрәкәткә китерү. *Фәез үзе дә көтмәгән оста хәрәкәт белән моторны кабызды.* Г. Мөхәммәтшин.

3. *күч.* Хис, тойгы, энергия һ. б. уяту, тудыру барлыкка китерү. *Күп кешеләрнең чырайларында һәм күзләрендә сөйләүченең үткен сүзләре кабызган тынгысыз кызыксыну чагылды.* Ә. Еники. — *Көйләрең дәрт кабыза торган, зур шатлык бирә торган булсыннар.* Р. Ишморат.

КАБЫК *и.* **1.** Агачның үзагачтан җиңел аерыла торган тышкы өске катлавы; кайры. *Абзыйлар шул озын һәм юан юкә агачларын --- кисеп аударалар һәм --- кабыкларын төшерәләр иде.* М. Гафури. *Монда --- кылый куян Усак кабыгын кимереп тик ята.* Ш. Маннур. || Төрле нәрсәләр өчен файдаланыла торган махсус эшкәртелгән карама яки юкәнең тышкы катлавы. *Күп тә вакыт үтмәде, кабыктан ясалган ишекне шыгырдатып ачып, --- Маһи әби өеннән чыкты.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Кабыктан эшләнгән. *Кая киткән ул әлеккә иске кабык арбалар.* Н. Исәнбәт.

2. Яшелчә, кайбер җиләк-җимешләрнең ашауга яраксыз тышчасы. *Суган кабыгы.* □ *Җирдә өшеп сыек яшел төскә кергән карбыз кабыклары аунап ята.* Г. Гобәй. || Нәрсәнең дә булса табигый каты тышчасы. *Көнбагыш кабыгы.* □ *Әйе, өч йомырканың коры кабыгы гына калган, эчен нәрсәдер бик чиста итеп суырып алган.* А. Алиш.

3. Кайбер умырткалы хайваннарның тәнен саклый торган каты пластинкалар (мәсәлән, елан, балык, кәлтә еланында). *Кәлтә җәенә берничә тапкыр кабыгын сала.* Зоология.

4. *күч.* Чынбарлыктан, тирә-юньнән аерып, нинди дә булса сферада гына чикләп, хәрәкәт итәргә, үсәргә комачаулаучы нәрсә. *Василий бер кереп алган кабыгыннан ничек тә чыкмаска тырышты.* Ә. Еники. [*Яңа*] *шәһәрчектә яшәүчеләр кешенең сулышын буып торучы --- борынгы кабыкларны җимереп ташлаганнар.* Г. Бәширов.

5. *күч.* Тышкы кием. *Извозчик, әллә минем тышкы кабыгым чибәр булганга, „Бристоль“ номерына туктатты.* Г. Тукай. *Мәдинә кебек акыллы кыз, кешенең тышкы кабыгына, күрер күзгә булган матурлыгына гына алданып, һуштан язмас.* Ш. Хөсәенов.

6. *күч. иск.* Мәетне зиратка алып бару өчен агач кабыгыннан ясалган махсус носилка. *Ак кәфенгә төрелгән Галиулланы өйдән алып чыктылар да кабык өстенә салдылар.* И. Гази.

◇ [Үз] **кабыгына гына бикләнеп (төренеп) яшәү** — тирә-юньдәге тормыштан аерылган булу.

КАБЫКЛАНУ *ф.* Нәрсәнең дә булса өске йөзе кабык белән каплану, өске тышча барлыкка килү.

КАБЫКЛЫ *с.* Кабыгы әрчелмәгән, чистартылмаган. [*Шәйхаттар*] *газета кәгазенә яшел суган, кабыклы бәрәңге, --- тоз ише вак-төяк нәрсәләр тезеп, ашарга әзерләде.* Г. Ахунов.

Кабыклы бака *иск.* — *к.* ташбака.

КАБЫКЧЫ *и. зоол.* Агач кайрысын һәм үзәген кимерүче кара яки коңгырт төстәге корткыч коңгыз. *Зур нарат кабыкчысы.*

КАБЫЛ-КОБЫЛ *рәв.* Кабаланып, ашык-пошык, тизтиз. *Искәндәр, балаларча итеп, кабыл-кобыл ашады да дәресләрен әзерләргә утырды.* Г. Минский.

КАБЫМ *и.* **1.** Бер генә мәртәбә кабарлык. *Тәүләкләр буенча* [*Зыя*] *ялгыз калса, шул сурәт* [*карт*] *алдына килеп, бер кабым нәрсә ашый алмый йөрде...* Г. Ибраһимов.

2. Кисәк, сыник. *Йөдәгәнеңне күрсә* [*Шәриф*] *--- соңгы кабымын авызыннан өзеп бирер.* Каз. утл.

КАБЫМЛЫК *и.* **1.** Аппетит өчен ашау алдыннан яки исерткеч эчемлекләр эчкәннән соң кулланыла торган ашамлык. *Дхәт рюмкаларга салды, кабымлык килгәнне дә көтеп тормастан --- эчеп җибәрде.* А. Гыйләҗев.

2. *к.* кабым. *Бер кабымлык калдырмый ашау.*

КАБЫНДЫРУ *ф. к.* кабызу. *Ярышны кабындырып җибәрү өчен колхозчының күңел ачкычын табарга кирәк.* Г. Бәширов.

КАБЫНУ *ф.* **1.** Яну, янып китү, яна башлау. *Ылыслар дары кебек кабынып китәләр дә күзләрне чагылдыра торган көчле яктылык белән чытырдап яналар.* Г. Әпсәләмов. *Караңгы зал кинәт яктырып китә, прожекторга утлар кабына.* һ. Такташ. || Яктырып, елтырап күренә башлау; калку (йолдызлар турында). *Күктә йолдызлар кабынгач, Галиулла янына Якуб килеп чыкты.* И. Гази. || *күч.* Нурлану, очкынлану (күзләр турында). *Командир елмайды, аның уйчан күзләре кабынып китте.* А. Шамов.

2. Эшли башлау (мотор, машина һ. б.). *Иртәләрнең берсендә менә берьюлы берничә моторның гөрләп кабынганы ишетелде.* Ф. Хөсни. *Кайнап чыга җирнең байлыклары, Таудай өелә кара алтыннар, Атылалар нефть фонтаннары, Кабыналар яңа мартеннар.* Ә. Исхак.

3. *күч.* Кинәттән нинди дә булса көчле хискә бирелү, ярсу, кызып китү. *Кызның тавышында ризасызлык та, ачу да, кисәтү дә ишеткән Хисами дарыдай кабынды.* Г. Минский. || Уяну, туу, барлыкка килү (тойгылар, хисләр турында). *Йолдызлар булып кабынды Мәхәббәт ялкыннары.* С. Хәким. *Нәфрәт уты кабына күңелдә.* Ф. Кәрим.

4. *күч.* Дәртләнеп эшли башлау, эшкә рухланып керешү. *Ялкын кебек кабынам эштә, Мин дәртләнәм, рухланам.* Ә. Ерикәй. || *рәв. мәгъ.* **кабынып.** Рухланып, дәртләнеп, янып. *Эшлик, дуслар, ярсып, кабынып, Көч һәм корал безнең кулларда.* М. Җәлил.

5. *күч.* Башлану, көчәю, киеренке төс алу (ижтимагый вакыйгалар турында). *Казанда да шундый ук вакыйгаларның* [*эшчеләрнең чыгышлары*] *кабынып китүе Вәлишинның бөтен тынычлыгын җуйды.* К. Нәҗми. *Сәгыйтов --- ике дистәгә якын эшчесен заводтан куып чыгарды. Ризасызлыклар моның белән генә сүнмәде, кабына барды.* Ә. Фәйзи. || Башлану, кузгалу, килеп чыгу (сүз, бәхәс, ярыш һ. б.). *Бәхәс кабыну.*

Сүз кабыну. □ *Ул арада әшелонга агитаторлар кереп, кабынып китә митинг.* И. Гази.

КАБЫРГА *и.* 1. *анат.* Умыртка баганасыннан күкрәк сөягенә дугаланып килгән тар сөяк. [*Сыерларның*] *--- иңбашлары таяк башыдай калкып, кабыргалары сырланып тора.* Ә. Еники.

2. *күч.* Гәүдәнең уң яки сул ягы, ян як. *Хаҗи йокысы илә бер кабыргадан бер кабыргага әйләнеп ята-ята --- уйлады.* Г. Тукай. *Ике яклап тезелгән юан терәүләр кабыргадан килеп кысарлар төсле күренәләр.* М. Гафури.

3. *күч.* Нәрсәнең дә булса чите, кырые, яны. *Очкычның канатларына, танкның кабыргасына: „Немец илбасарларына үлем!" — дип язылган иде.* А. Әхмәт.

4. Ике яссылыкның кисешү сызыгы. *Кубның уникә кабыргасы бар.* Геометрия.

5. *күч.* Берәр урынның кабырга сыман калкуланып торган жире. *Бераз эзләп йөргәннән соң, [Габделкаюм] бер кабыргада әлегә бер дә кеше кулы тимәгән җиләклек тапты.* М. Гали.

◇ **Кабыргага төрттерү (төртеп тору)** — 1) читләтеп әйтү, төрттереп, кадап әйтү. *Анысын кабыргага төрттермичә дә беләбез, бригадир иптәш! — диде [Гөлсем].* Г. Бәширов; 2) тәнкыйтьләү, кимчелекләрне әйтү. — *Рәхимҗан картның кабыргаңа төртеп торуы ошамады сиңа.* Р. Ишморат. **Кабыргасын санау (тетү, каезлау)** — кыйнау. [*Яшьләр*] *бер җаен табарлар да аның кабыргаларын санарлар.* Г. Ибраһимов. *Егетләр (һәммәсе ябырылып дпрәүгә ташланалар). — Тет кабыргасын буржуйның.* М. Фәйзи. [*Илдус:*] *Ярый әле танымады. Папиросым өчен кабыргамны каезлар иде.* Д. Аппакова. **Кабыргалары күренеп (беленеп) тора** — артык ябык, арык. [*Бикмуш бабайның*] *кабыргалары беленеп торган арык тәне камчы эзе белән тулган.* Г. Гобәй. **(Мәсьәләне) кабыргасы белән кую** — кискен, катгый кую; ачыктан-ачык әйтү, таләп итү. *Председатель алдына кабыргасы белән куярга: быелдан калмый фермада водопровод, автопоилка булсын.* Ә. Еники. *Мин алай-болай сүз ишетсәм, мәсьәләне кабыргасы белән куярмын.* С. Рафиков. **Кабыргасы юка** — ябык, зәгыйфь, көчсез (кеше турында). [*Егетнең*] *кабыргасы юкарак.* Ш. Камал.

КАБЫРГААРА *с.* Ике кабырга арасындагы. *Кабыргаара мускуллар һәм диафрагма сулыш хәрәкәтләрендә зур роль уйныйлар.* Анатомия.

КАБЫРГАН *рәв. иск.* Яны белән. *Солдатлар аларга кабырган баруга карамастан, күзләре һаман әшчеләр ягында иде.* М. Гафури.

КАБЫРЧЫК *и.* 1. Күп кенә умырткасыз хайваннарның үзен саклый торган каты тышкы кабыгы. [*Рәшитнең*] *бер кулында чәчәкләр, әкәм-төкәмнәр, бака кабырчыклары.* Р. Ишморат. || Нәрсәнең дә булса катламлы тышчасы. *Иртәләрен тау битләре, брезент палаткаларның өсләре ялтыр, нечкә боз кабырчыгы белән каплана.* Ә. Айдар.

2. Куыкчык. [*Бетон салганда*] *күзең үткен булырга тиеш! Бер генә кабырчык та, буш урын да калмасын.* А. Гыйләҗев.

Кабырчык кисәү *а.—х.*—үсемлекнең сабагында, чәкәнендә, яфрагында була торган кара тузанлы төрле зурлыктагы төер (кукуруз авыруы).

КАБЫРЧЫКЛАНУ *ф.* Кабырчыклар (1 мәгъ.) белән капланган. *Көмеш кабырчыклы, сөңгеле сакчылар, җәен кыяфәтле вәзир һ. б. (керә).* Н. Исәнбәт.

Кабырчыклы тимрәү *мед.* — ак төстәге кабырчыклар белән капланган, озак төзәлми торган йогышсыз тимрәү.

КАВАЛЕР *и.* 1. *сөйл.* Өйләнмәгән егет. *Күпшы сакал-мыеклы фырт кавалерлар бакча аллеяларын тутырып гөр килеп йөриләр.* А. Расих. || Парлы танецта хатын-кыз белән биюче ир кеше. || *иск.* Буржуаз-дворяннарның кунак мәҗлесендә хатын-кызга аеруча илтифат күрсәтеп, аның кәефен табарга тырышучы ир кеше. *Алтын, ефәк, атлас әченә чумган матур ханымнар, погонлы, төз буйлы, тәрбияле кавалерлар.* Г. Ибраһимов.

2. Нинди дә булса орден белән бүләкләнгән кеше. *Алтын йолдыз кавалеры.* □ *Дан ордены кавалеры кече лейтенант, өлкән офицерның үзенә таба килгәнлеген күргәч, аягүрә басты.* Г. Әпсәләмов.

КАВАЛЕРГАРД *и. иск.* Патша армиясендә атлы гвардия полкында хезмәт иткән солдат яки офицер. *Кавалергард полкы.*

КАВАЛЕРИСТ *и.* Атлы гаскәрдәге хәрби хезмәткәр; атлы сугышчы. *Кавалеристлар коралларын, иярләрен уңайлый, үзара сөйләшә, шаулаша, тәмәке тарта башладылар.* А. Шамов.

КАВАЛЕРИСТЛАРЧА *рәв.* Кавалеристлар кебек. *Кавалеристларча киенгән Нургали керә.* Т. Гыйззәт.

КАВАЛЕ'РИЯ *и.* Атлы гаскәр. [*Солдатлар*] *тау менеп, урман авызына килеп җиткәндә, болар кузгалган урында зур гына кавалерия отряды күренде.* М. Гали.

КАВАЛЬЕР *и. махс.* Канау һәм канал казыганда кырыйга өелгән туфрак, балчык. || Юлны агып килгән сулардан, кар көртеннән саклау өчен аның як-ягына туфрактан өелгән өем.

КАВАЛЬКА'ДА *и.* Сәйранда йөрүче атлылар, җайдаклар төркеме. *Ул бер-ике йөз метрлар китеп өлгермәде, тау башыннан атлы кавалькада килеп чыкты.* Ә. Айдар.

КАВАСА'КИ *и. махс.* Ерак Көнчыгышта яр буенда балык тоту өчен файдаланыла торган моторлы көймә.

КАВАТИ'НА *и. муз.* Операда кечерәк кенә лирик ария.

КАВДИВИ'ЗИЯ *и.* Кавалерия дивизиясе. *Шул көннәрдә Нуруллиннар кавдивизиясенең дошман гаскәрләре артына кереп ясаган мәшһүр рейды башланды.* А. Шамов.

КАВЕМ *и.* 1. *сөйл.* Ерактан килгән кардәшлек, нәсел. [*Сөләйман:*] *Үзем дә аптырыйм, бу Уразмәт кавеменә кайдан шундый чирләшкә килеп эләкте икән.* Г. Әпсәләмов.

2. Халык, халык төркеме. *Һәр тарафта күпме кавем гомер кичкән чын табигать.* Х. Сарьян. *Сүзеңә караганда — гарәп, киемеңә караганда — француз, ә күңеленә караганда, син башка бер кавем кешесенә охшыйсың.* Ш. Усманов.

3. *күч.* Токым, зат. *Ябырылып килгән дию кавемен кымшанмаслык итеп туктатыйк.* Ф. Кәрим. *Хатын-кыз кавеме башта бик тәкәббер, һавалы була.* Т. Гыйззәт.

КАВЕМ-КАБИЛӘ *и.* Туган-тумача (ерак туганнарны да кертеп). *Кавем-кабилә, ыруг-кардәшләрегез хәтсез генә икән, Җәләлетдин әфәнде.* Ш. Камал.

КАВЕ'РНА *и.* 1. *мед.* Авыру сәбәпле берәр органның тукымасы таркалып барлыкка килгән бушлык. *Бик җентекләп тикшергәннән соң, доктор Дьяков Галимҗанның уң үпкәсендә бик зур каверна --- булганын әйтте.* Каз. утл.

2. *геол.* Тау токымындагы бушлык, куыш урын.

КАВКАЗЛЫ *с.* Кавказда яшәүче, чыгышы белән Кавказдан булган. *Кавказлы Гәрәй Солтан дәшми тыңлап тора-тора да бер сүз әйтмичә чыгып китә.* Г. Ибраһимов.

КАВКАЗЧА *рәв.* Кавказлыларга хас, кавказлылар кебек. *Кавказча бию.*

КАВЫЗ *и. диал.* Тегермәнгә һ. б. ш. су бирү өчен такта, таш җәеп ясалган махсус улак. *Кавыз ябу.* □ *Ничек кенә булса да вакытлы буабызны күтәрергә, --- казылып бетмәгән кавыз юлын ачарга.* Т. Гыйззәт. [*Гөлбәдрия җиңги:*] *Таш түшәү, мөшкә кору, кавыз җәю дисеңме — барысын да ул бәрүзе эшләп җиткерә торганые, балакаем.* Ш. Маннур.

КАВЫК *и.* Баш тиресе күзәнәкләренең үлеп, чәч төбенә җыела торган вак кисәкләре. *Секретарьның йөзенә каткан елмаюы һәм җилкә-иңнәренә мул булып кавык коелган кара костюмы гына аның хәтерендә калган.* М. Хәсәнов.

КАВЫКЛАУ *ф.* Кавык барлыкка килү, кавык белән капланау. *Баш кавыклаган.*

КАВЫКЛЫЛЫК *и.* Кавык күп булу, кавыклы булу. *Башның кавыклылыгы.*

КАВЫМ *и.* Кыска гына вакыт, бераз гына, әз генә бер ара. *Куян --- бер кавым чапты да борылып карады.* Г. Бәширов. *Бер кавымга безнең Сәмигулла бар дөньясын онытты.* С. Рафиков.

КАВЫН *и.* 1. Кабакчалар семьялыгыннан бакчаларда үстерелә торган эре җимешле яшелчә үсемлеге. *Ирләр --- кавын, карбыз һәм бәрәңгегә билгеләнгән җирдән агач тамырлары төпләргә киттеләр.* Ш. Камал.

2. Шул үсемлекнең түгәрәк яки озынча формадагы сусыл, татлы эчле җимеше. *Борынны кытыклап, төче кавын исе керде.* А. Расих.

КАВЫН-КАРБЫЗ *җыйм. и.* Карбызлар һәм кавыннар; гомумән, шундый татлы бакча яшелчәләре. *Бакчалардан кайта авылларга кавын-карбызлар.* М. Җәлил.

КАВЫНЛАНУ *ф.* Кавынның чәчәге коелып, төймә барлыкка килү.

КАВЫНЧЫ *и.* 1. Кавын сатучы, кавын белән сәүдә итүче.

2. Кавын үстерүче, кавын үстерүче белгеч.

КАВЫНЧЫЛЫК *и.* Кавын үстерү белән шөгыльләнү. *Кавынчылык хуҗалыгы.*

КАВЫРСЫН *и.* 1. Кош канатындагы эре каурый. *Һаваларда очкан асыл кошның Кавырсынын алдым каләмгә.* Җыр.

2. *диал.* Пластмасса. *Хуҗа үзе әйбәрләр арасыннан кавырсын стаканнар эзләп алып килде.* Г. Ахунов.

Кавырсын каләм *иск.* — каз каурыеннан ясалган каләм. *Дәфтәрләр мөселманча һәм кавырсын каләм белән язылачак.* Ш. Мөхәммәдев.

◇ **Кавырсыны кату** — үсеп буыннар ныгып җитү, балалыктан чыгу. *Кавырсыны яңа гына ката башлаган үсмерләрне һәр көн саен --- сугышка озата тордылар.* А. Гыйләҗев.

КАВЫШТЫРУ *ф.* 1. Аерылып торганнан соң очраштыру, бергә туры китерү. *Тормыш дулкыннары безне кавыштырыр тагын да.* Ә. Ерикәй. || Очрашырга, күрешергә мөмкинлек бирү (гашыйклар турында). *Зыя өенә дә һәр җәйдә кайта, --- [Мәрьям белән] кеше алдында күрешеп сөйләшү-фәлән мөмкин булмаса да, караңгы төннәр аларны кавыштыра.* Г. Ибраһимов.

2. Бергә тора башларга мөмкинлек бирү. *Таңчулпан белән Кәрим дә бер-берсен сөйгәннәр, ләкин ата-аналары аларны кавыштырырга теләмәгәннәр, чөнки Кәрим бик ярлы булган.* Г. Әпсәләмов.

КАВЫШТЫРУЧЫ *и. иск.* Егет белән кызны, ир белән хатынны кавыштырып йөрүче; яучы. *Камилә абыстай — егетләр берлә кызларны сөйдерүче һәм кавыштыручы хатын.* Г. Коләхмәтов.

КАВЫШТЫРУЧЫЛЫК *и. иск.* Ир белән хатынны кавыштыру, арадашлык итү белән шөгыльләнү.

КАВЫШУ *ф.* 1. Аерылып торганнан соң очрашу, яңадан бергә булу. *Язмыш дулкыннары белән бер кавышып, бер аерылып яшәгән дүрт иптәшем дә шул авылның төрле урамнарында байлыгы-төзеклеге төрлечә булган төрле өйләрдә туып үстеләр.* Г. Ибраһимов. *Бар, җаным, инде яшел урманга оч, Тиз ятим кошчыкларың берлән кавыш.* Г. Тукай. || Очрашу, күрешү (гашыйклар турында). *Кавышулары, иркәм, бик күңелле, әмма аерылышу бик яман.* Җыр.

2. Кушылу, ир белән хатын булып бергә тора башлау. *Таһир — батыр, Зөһрә — матур, Алар да кавыша алмаган.* Җыр. [*Газинур:*] *Ә туйны кайчан ясыйбыз соң, Миңнурый? Кайчан кавышабыз?* Г. Әпсәләмов.

КАГАЙТУ *ф.* 1. Һавада, җилдә тотып киптерү, каклау (итне, балыкны һ. б.).

2. *күч.* Ач тотып азаплау, ач тотып ябыктыру.

КАГАН *и. тар.* Урта гасырларда төрки халыкларының хөкүмәт башлыгы титулы һәм шул титулга ия булган кеше. *Габдулла, пошынып, ачынып, каганның мөселманнарны әзәрлекләве --- турында сөйләде.* Н. Фәттах.

КАГАНАТ *и. тар.* Башында каган титуллы кеше торган хөкүмәт. *Төрек каганаты.* □ *Болгар культурасы үзе Хозар каганатына һәм Алтын Урдага кергән башка халыкларның --- культура йогынтысын татыган.* Каз. утл.

КАГАНЛЫК *и. тар. к.* каганат.

КАГАЮ *ф.* 1. Җилдә кибү, каклану (мәс., балык, ит һ. б.).

2. Озак вакыт эшсез бер урында тору. *Сираҗие, мескен, кылый Макар янында тик кагаеп тора.* К. Нәҗми.

3. *күч.* Ябыгу.

КАГОР *и.* Кызыл аракының бер төре.

КАГУ *ф.* 1. Шаку; ишек, тәрәзә, стена һ. б. ш. нәрсәгә җиңелчә бәргәләү. *Кемдер тәрәзә кага иде.* Ш. Камал. *Сөләйманов, --- юаш кына өстәл кагып, халыкны тәртипкә чакыра.* Ә. Еники.

2. Берәр нәрсәгә бәреп, сугып сигнал бирү. *Эшкә чакырып кырда чаң какмылар.* М. Җәлил. *Вожатый тиз генә башаклар өеме янына килеп барабан какты.* Г. Гобәй.

3. Ярга бәрү (дулкыннар турында). *Су акканны ишетсеннәр өчен, дулкыннары барып --- ярларны кага.* Ф. Кәрим.

4. Кадак, казык, чөй кебек нәрсәләрне бәреп, сугып кертү. [*Бикбулат*] *зур агач тукмак белән әһелди-әһелди казык кага иде.* Г. Бәширов. [*Итекче*] *авызын тутырып вак кадаклар каба да чүкеч белән шуларны берәмләп ботинка төбенә кага башлый.* Ә. Еники.

5. *к.* кадаклау (1 мәгъ.). *Кытлык елны инде туры килде Тәрәзәләргә такта кагарга.* Ш. Маннур.

6. Берәр нәрсәне суккалап яки селкеп, тузаннан, чүптән һ. б. арындыру, чистарту. *Келәм кагу.* □ *Рәүфә тиз генә сикереп торды да --- бишмәтенә, шәленә сырышкан кибәкне ашыгып-ашыгып кагарга тотынды.* А. Шамов.

7. Әйбер эченә тулган нәрсәне селкеп бушату, түгү. [*Бәдри*] *самоварны алып, тиз генә кагып, су салып, мич алдына утыртты.* М. Гафури. || *күч.* Бушату, соңгысын алып тоту (азык, акча һ. б. турында). *Теләгән җиргә агарбыз, бумажникларны кагарбыз.* Ш. Мөхәммәдев. *Ә шулай да, тәмәкесе булса, Бергә кага идек янчыгын.* Ш. Маннур.

8. Яратып, иркәләп аркадан, иңбаштан сөю. *„Шулай тырышып укыгыз инде!“ — дип,* [*Динмөхәммәт карт*] *икесенең дә аркаларыннан кагып куйды.* М. Гали. || Баланы йоклатканда яки юатканда кул белән йомшак кына чәбәкләп, бәргәләп тору. *Баласы елый, аны кагып юаткан була.* М. Гафури.

9. Җилпү хәрәкәте ясау (кошлар канаты турында). *Киң тугайда канат кага бер тургай.* Ә. Ерикәй. *Куначадагы этәч, канат кагып, актыккы мәртәбә кычкыра да пырылдап җиргә төшә.* А. Шамов.

10. Атны кузгалырга яки йөрешен тизләтергә әйдәп дилбегәне, өзәнгене җиңелчә генә селкетеп, сугып кую. *Дилбегәне кагуга --- алаша элеп алып китте.* Г. Гобәй. *Тезген тартып, шпор кагу белән, Җиргә сузылып ята бу атлар.* Ф. Кәрим.

11. Җилфердәтү, селкетү (җил турында). *Яңа гына күңелле шаулап утырган агачлар, яфрак та кагарга бәвмыйча, юаш кына басып торалар.* И. Гази.

12. Еш-еш, нык бәреп тибү (йөрәк турында). *Мисбахның йөрәге сикереп-сикереп кага.* Г. Әпсәләмов.

13. Нәрсәне дә булса читкә этәрү, бәреп чыгару. *Көчле агым барыбер [боз кисәкләрен] кереп туктал-ган кечкенә култыклардан кагып чыгара.* Ә. Фәйзи.

14. *күч.* Исерткеч әчемлек эчү. — *Ярты ны кагыйк, җәмәгать, кем керә, давай пайга.* З. Мансур.

15. *күч.* Кыерсыту, рәнҗетү, чит итү. *Азмы кактанны вә сукканны күтәрдем мин ятим?!* Г. Тукай. *Малайны кагып әйткән сүз түгел, үзең беләсең, кызып киткәч, үзеннән-үзе сүз чыга.* Ф. Хөсни.

◇ **Каккан казыгы да юк** — бернәрсәсе дә юк, үтә ярлы. [*Идият абзыйның*] *йорт-җире түгел, каккан казыгы да булмаган, ди.* Ә. Еники.

КАГУ-СУГУ *ф.* Кыйнау, кыерсыту, җәберләү. — *Кызымны, Зөһрәмне, үзең дә рәнҗетмә, кешеләрдән дә рәнҗеттерми генә, какмый-сукмый гына үстерсәнә.* А. Әхмәт.

КАГЫЙДӘ *и.* **1.** Нинди дә булса күренешләрнең закончалыкларын, үзара мөнәсәбәтләрен чагылдыра торган тезис, билгеләмә, положение. *Грамматика кагыйдәләрен бозулар очраштырганлый.* М. Җәлил. *Мостафа* [*мылтыктан*] *төзәүнең гомуми кагыйдәләре белән кыскача таныштырды.* Ш. Камал.

2. Нинди дә булса гомуми тәртип урнаштыруга карата рәсми кабул ителгән, расланган күрсәтмә. *Эчке тәртип кагыйдәләре.* □ *Техника хәвефсезлеген саклау кагыйдәләренең тупас рәвештә бозылуына кем юл куйган?* С. Рафиков. || Гадәткә, традициягә кергән тәртип, үз-үзеңне тоту нормасы. *Шакир катгый гына бер хәрәкәт белән урыныннан торды да, рәсми нәзакәтне кагыйдәләре белән җиренә җиткереп, кыска вә коры гына дсма белән саубуллашты.* Ф. Әмирхан.

Кагыйдә буларак *кер. сүз.* — гадәттә, нигездә кабул ителгәнчә. *Барлык шигырьләремне, көндәлекләремне, язмаларымны, кагыйдә буларак, сиңа җибәреп торырмын.* М. Җәлил.

КАГЫЛГЫСЫЗ *с.* **1.** Билгеле бер вакытка кадәр тотылмый саклана торган. *Кагылгысыз запас.*

2. Кемнең булса кул сузуыннан закон тарафыннан саклана торган. *Кагылгысыз социалистик милек.*

КАГЫЛГЫСЫЗЛЫК *и.* Кагылгысыз булу. *Парламент кагылгысызлыгы хокукы.* □ *Депутатларның кагылгысызлыгы, шулай ук депутатлык эшчәнлегенең башка гарантияләре --- закон актлары бәлән билгеләнә.* СССР конституциясе.

КАГЫЛМА *диал. и. к.* салу. — *Менә монда* [*юл борылышында*] *бик әшәке кагылма ясалган.* Ш. Камал.

КАГЫЛМАЛЫ *с. диал. к.* салулы. *Кагылмалы кышкы юлдан җирән кашка әйбәт кенә юырта.* И. Гази.

КАГЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* кагу. *Кемнәрдер* [*өстәл*] *такталарын каерып алып киткәннәр, бары тик җиргә кагылган ике аягы гына тырпаеп калган.* Г. Әпсәләмов.

2. Кемгә яки нәрсәгә булса да орыну, тию, җиңелчә генә бәрелү. [*Нәфисә*], *кулы белән рәшәткәләренә кагыла-кагыла, бакча буенча уза, капка яныннан әйләнеп килә.* Г. Бәширов. [*Зыяның*] *куллары кылга кагылу белән, музыка елый башлар.* Г. Ибраһимов. || Килеп бәрелү, тию. *Суны ярып йөзә пароходлар, Чал дулкыннар ярга кагыла.* Җыр.

3. Юлдан, баскан, утырган урыннан тайпылу, чыгу. [*Гали*] *атлы тавышын ишетеп, юлдан читкәрәк кагылды.* Ш. Камал. [*Хәят*], *Михаил --- йөзенең бу кадәр якын торуыннан курыккан сыманрак итеп, читкәрәк кагылды.* Ф. Әмирхан.

4. Кемгә яки нәрсәгә дә булса тию, орыну. *Мин аңа этиеңнең әйберенә кагылма дип ни әйттем, тыңламады.* Д. Аппакова. || *күч.* Берәр нәрсәне үзенеке итү, алу, үзләштерү. *Бу малай сүзенә ышанма, Мирсәет туган, колхоз милкенә кагылырга Гаптелмәннең башына тай типмәгән.* Р. Ишморат.

5. Берәрсенә яки берәр нәрсәгә карау, кагылышлы булу. *Кичә сессиядә сөйләгән сүзләр алар бер Нургали абыйга гына түгел, ферманың барлык кешеләренә дә кагыла бит.* Ә. Еники. — *Сузарга ярамый торган тагын бер эш бар икән әле, Айдар Гафиятович, --- бусы синең үзеңә генә кагыла.* Ф. Хөсни.

6. Нәрсәгә дә булса тукталу (искә алу, билгеләп үтү өчен). *Татар театры турында яза башласаң — Галиәсгар Камалның тормышына һәм иҗатына кагылмый һич мөмкин түгел.* М. Гали.

7. Юл уңаенда кая булса сугылу, кереп чыгу. [*Хәлим*], *кайтышлый Шәрифҗан абыеңа да кагылырсың.* И. Гази. || Йомыш белән килү. *Аңа-моңа барып кагыласың, Аермыйсың дусны, дошманны, Йөз суыны түгеп ялынасың, — Чәчтерергә кирәк сабанны.* Ш. Маннур.

КАГЫЛУ-СУГЫЛУ *ф. төш. юн. к.* кагу-сугу. | *и. мәгъ. Ятим үскән, балачак иркәлеген татымаган, җиде-сигез яшеннән үк этисе белән көтү көтә башлаган һәм колхоз оешканга кадәр кышларын кулакларга батрак булып эшләгән, алардан хәтсез күп кагылу-сугылуларны күргән бу яшь егеттә кайдан шулкадәр көр күңеллелек, кайдан шулхәтле үз-үзенә ышану?* Г. Әпсәләмов.

◇ **Кагылып-сугылып йөрү** — кая барырга, нәрсә эшләргә белмичә аптырау. [*Җәмилә*] *кагылып-сугылып йөри торгач, таныш ларыннан ишетеп, --- шырпы фабригына* [*эшкә*] *барып керде.* М. Гафури.

КАГЫЛЫШ *и.* Мөнәсәбәт, бәйләнеш. *Аның моңа кагылышы юк.*

КАГЫЛЫШЛЫ *с.* Кагылышы булган. *Мин либреттоның сәхнәгә кагылышлы моментларына да тукталып тормадым.* М. Җәлил. [*Сүз*] *үзебезнең тормышка кагылышлы мәсьәләләр турында бара.* Г. Ахунов.

КАГЫЛЫШУ *ф. к.* кагылу (3 мәгъ.). *Коридор тулы яшьләр, кагылышып, Богдасаровка, аны озата чыгучыларга юл бирделәр.* И. Гази.

КАГЫҢУ *ф.* **1.** Канатлар белән җилпенү (кошлар турында). *Төркем-төркем казлар --- бик яман каңгылдашалар һәм киерелеп-киерелеп канат кагыналар иде.* Ә. Еники. *Моңайганда, егет, бер җырласаң, Асыл кошлар канат кагыныр.* Җыр.

2. Өс киемендәге кар, тузан, чүпләрне кагып чистарту, каккалап төшерү. *Килүче хатын шәлен салып кагынды, тунын чишеп җибәрде.* А. Шамов. *Бәдәр торып басты, Акрын гына өстен кагынды.* Ш. Мөдәррис.

Кагыну каурыйлары — кош канатындагы иң эре һәм каты каурыйлар.

КАДАВЫЧ *и.* Нәрсәне дә булса кадап куя торган әйбер. *Тартманы төрле әйберләр: кәтүкләр, --- әнә һәм --- кадавычлар, кайчы --- салу өчен берничәгә бүләргә кирәк.* Һөнәрленең кулы алтын.

КАДАК I *и.* **1.** Бер башы очлы, икенче башы эшләпәле, гадәттә, металлдан ясалган һәм бер нәрсәне икенчесенә кагып беркетү өчен хезмәт итә торган

әйбер. *Миңнулла иреннәре арасына кыскан кадакларның берсен алды да, тактаны җайлап куеп, кадакка чүкеч белән шалт-шолт сугa башлады.* И. Гази. *Тырышкан табар, ташка кадак кагар.* Мәкаль. || Әйберләр элү өчен кагылган агач яки металл чөй; элгеч. *Шәрифулла алъяпкычын салып, кадакка элеп куйды.* А. Шамов. *Варис чишенеп, пальтосын ишек катындагы кадакларның берсенә элде.* М. Хәсәнов.

2. *күч.* Берәр мәсьәләнең, күренешнең үзәге, иң әһәмиятлесе. *Орлыкны ничек җиткерергә, планны ничек йөз процент итәргә? Менә кайда хәзергесе көннең кадагы!* Г. Бәширов.

Кадак борау *махс.* — тишек бораулау өчен махсус кечкенә борау. **Кадак суыргыч** *махс.* — кадак суыру коралы (башы ике җәпле кәкре тимер).

◇ **Кадак булып кадалу** — берәр уй, фикернең башка кереп утыруы, тынгылык бирмәве. *Жандарм белән прокурордан бер якта, --- Тарбашевны күргәч, Гәрәй Солтанның миенә кадак булып бер уй кадалды: „Кайдан алып китәрләр?“* Г. Ибраһимов.

КАДАК II *и. сөйл.* 409,5 *гр* га тигез булган авырлык үлчәве. *Хәсән, куршедәге кибеткә чыгып, бер кадак күмәч, ике тиенлек сөт алып керде дә чәй эчәргә утырды.* Ф. Әмирхан. *Кечкенә бер капчыкка ун кадак чамасында ярма салынган.* М. Гафури.

КАДАКЛАНУ *ф. Төш. юн. к.* кадаклау 1. — *Усакка кадакланган бер фанера кисәгенә күзем төште.* А. Шамов.

◇ **Кадакланган кебек (шикелле)** — селкенмичә, билгеле бер хәлдә. [*Зифа әби*] *кадакланган кебек, тәрәзә төбендә катып калды.* Г. Ибраһимов. [*Ат өстендә малай*] *кадакланган шикелле утырган да, кулларын як-якка болгаштырып, очып кына килә.* Ф. Хөсни.

КАДАКЛАУ *ф.* 1. Берәр нәрсәне икенче бер әйбергә кадак ярдәмендә беркетеп кую. [*Якуб*] *каерылып ташланган ишек тактасын кадакларга тотынды.* И. Гази. || Ишек, тәрәзә, ящик һ. б. ш. нәрсәләрне такта белән бикләп, ачылмаслык итеп кую. [*Гайнавал:*] *Тәрәзә-ишекләрне такта белән кадакладык. Искәрә торыгыз.* Т. Гыйззәт.

2. Белдерү, стенгазета һ. б. ларны кая булса да беркетү, кагу, элү. [*Мостафа*] *кәгазь өстенә кара белән алма ясап, кәгазьне 50—60 м чамасы читтәге өянке агачына кадаклап куйгач, винтовкалар белән төзәргә өйрәтә башлады.* Ш. Камал. *Сәлимнәр --- кичә колхозның стена газетасын күчереп яздылар һәм --- олы класслар ясап биргән витринага кадаклап куйдылар.* Г. Гобәй.

3. *тар.* Җәзалау ысулының бер төре турында. *Яңалык һәм ирек сөйгән өчен [эткәемне] Баганага кадаклаганнар.* Ә. Ерикәй. *Ул ут бирде мазлум халыкларга, Ул фән бирде бәхет табарга, Д дошманым аны шуның өчен Кадаклады кыя тауларга.* Г. Кутуй.

◇ **Кадаклап куйгандай** *сөйл.* — *к.* кадакланган кебек. [*Бикбулат*] *--- ары-бире тилпенгәләп карый да, итәкләреннән кадаклап куйгандай, баскан урыныннан кузгалып китә алмый иде.* Г. Бәширов.

КАДАКЛАП *рәв.* Кадак-кадак итеп, бер кадак кына ясап (алу, бүлү, үлчәү). *Дледән-әлегә мулла дхмәтжаннан [әфьюнны] берәр кадаклап алдырта.* Г. Камал.

КАДАКЛЫ *с.* Бер кадакка тигез булган, бер кадак авырлыгындагы. *Бик яхшы агартылган мич буена ярты баш шикәр, кадаклы чәйләр, буй-буй сабыннар тезелгән.* Г. Ибраһимов.

КАДАКЧЫ *и.* Кадак ясаучы.

КАДАЛДЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* кадалу.

2. *күч. сөйл.* Үтерү, юк итү. — *Чәнчелдереп, кадалдырып җибәрермен.* Г. Камал.

КАДАЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* кадау (1, 3, 4 мәгъ.).

2. Аш юлында, тамакта утырып, кереп калу (сөяк, кылчык һ. б. турында). — *Карагыз, — диде Нәсимә, — ашыкмыйча гына ашагыз, [балыкның] вак сөякләренә кадала күрмәгез.* Ш. Камал. || Тәнгә ябышу, керү (бөҗәкләр турында). *Дгәр тәнгә талпан кадалса, аны шунда ук алырга кирәк.* Соц. Тат.

3. *күч.* Текәлеп, төбәлеп, сөзеп карау. *Тикшерүче, бер секунд аерылмастан, кочагарның күзләренә кадалды.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Баштүбән егылу, килеп төшү. *Җамали алар артыннан ачыклыкка йөгереп барды һәм анда бер аэропланның башы белән кадалып төшеп килгәнен күрде.* М. Гали. || Йөгереп килеп, баш белән карга, суга һ. б. чуму. [*Кыз*] *ташлана биек сикергечтән, Аткан уктай, суга кадала.* Ф. Кәрим.

5. *күч. гади. с.* Үлү, юкка чыгу. — *Өч-дүрт разбойник кадалганда нәрсә булыр дисең?* Ш. Камал. *Хөснижәмал әйтә икән: „Мин киявгә барам“, дип; әнкәсе аңар әйтә икән: „Бармагаең, кадал“, дип.* Ф. Әмирхан. || *тирг. боер. форм.* Кирәге юк. *Кадалып бетсен базары, асты-өскә килеп бетсен Гайнетдин компанияләре-ниләре белән!* Ә. Фәйзи. *Кадалсын умартасы, бакчасы! — дип, Бөтенесен, куллар селтәп, ташлап китә.* Ш. Бабич. || *тирг.* Үткән заман сыйфат фигыль һәм теләк фигыль формаларында каргау, тиргәшү сүзе буларак кулланыла. — *Дй, кадалган, кая китте соң.* □ [*Сафура:*] *Һай, кадалгыры, кабахәт эт, бирермен мин сиңа бөлеп кайтып килгәнне, баеп кайта дип әйт.* А. Алиш.

6. *күч.* Комсызланып ташлану, ябырылу. *Ачыгып беткән атларым арышка кадалалар.* Ш. Әхмәдиев.

◇ **Кадалып ашау** — *к.* кадалу 6. *Көндезге эсседә борчылган сыерлар хәзер кадалып ашыйлар.* А. Гыйләҗев. **Кадалып йөгерү (чабу, агу)** — бик зур тизлек белән йөгерү (чабу, агу). [*Әлимгул*] *кадалып аккан Агыйделне минут эчендә кичеп чыгып, Базарлыга таба юыртты.* М. Әмир. **Кадалып утыру** — тирә-юньдәгеләргә игътибар итмичә, нәрсә белән дә булса мәшгуль булу. *Китапханәгә йөгерәм һәм тәмам ябылу минутына чаклы китапка кадалып утырам.* Ф. Хөсни.

КАДАУ *ф.* 1. Очлы үткен нәрсә белән чәнчү. *Врачның бик тыныч кына укол кадавын, тагын әллә ниләр эшләтүен күргәч кенә Хәдичә тутинең эченә бераз җылы керә иде.* Г. Бәширов. *Бер рус солдаты, конвой башлыгының артыннан җитеп, аны штык белән кадап үтерде.* М. Гали. || Чәнчеп авыртгыру (чагучы бөҗәкләрнең угы, чәнечкеле үсемлекләр һ. б. турында). *Шаян малайның борын очына гына [бал корты] үзенең угын кадады.* А. Алиш. || *күч.* Организмда чәнечкәндәге шикелле кискен авырту тою. *Йөрәк кадый.*

2. Очлы әйберләрне берәр җиргә көч белән батырып, кертеп кую. *Солтангәрәй көрәген җиргә кадады.* Г. Гобәй.

3. Нәрсәне дә булса булавка, әнә һ. б. лар белән әләктереп, беркетеп кую. *Алма чәчәген өзеп ал, Күкрәгенә кадарсың.* Җыр. || Тегеп беркетеп кую (мәс., сәдәф, каптырма һ. б.). [*Җамали*] *шулай „машинача“ эшләп төймәләрне кадады, җиңнәрен утыртты да киң сәкегә җәеп үтүкләргә тотынды.* Г. Ибраһимов.

4. *күч. кимс.* Тиешсез урынга, файдасызга утыртып кую, бастырып кую. [*Президиумга*] *сайлап өстәл янына кадаганнар да үзен [Нурмөхәммәтне], әше беткән. --- Ник бер сүз дәшсен.* Ш. Камал.

◇ **Кадап куйган кебек (казыктай, казык кебек), кадап куйгандай** — селкенмичә, кымшанмыйча. *Безнең өч солдат менә шул кадап куйган казыктай тик кенә торган немец алдына килеп бастылар.* Ә. Еники. **Кадап әйтү** — үзәккә үткәреп, бик каты әйтү.

Гыймади --- Гомәрнең кадап әйткән сүзен тыныч кына үткәреп җибәрә алмады. И. Гази. [*Сүзен*] *турыдан-туры* [*тегүченең*] *күзенә карап, бәгыренә кадап әйткән булыр иде дә бит* [*Җәмилә*], *мәсьәләнең икенче ягы бар.* М. Әмир.

КАДАУЛЫ *с.* Кимсетүле, мыскыл итә торган. *Кадаулы сүзләр.*

КАДЕР *и.* 1. Хөрмәт, тирән ихтирам. *Мин* [*кайгыртучанлыкны*] *данлы Кызыл Армиябезгә һәм совет язучыларына күрсәтелгән игътибар һәм кадер дип карыйм.* М. Җәлил. *Пакь кием кадер арттырыр.* Мәкаль.

2. Кемгә-нәрсәгә тиешле бәя. — *Син, Нәсимә, яшь кеше булганга, ахры, авыл кешесе эшенең кадерен аңлап бетермисең, колхозчының хезмәтенә бәя биреп җиткермисең.* А. Әхмәт.

3. Абруй, авторитет, дәрәҗә. — *Үз кадерегезне үзегез җүеп, кыланып маташасыз.* Г. Минский.

Кадергә кия торган — кешелеккә, яхшыга гына кия торган (кием). *Кадергә генә кия торган җәйге чалбарымны арттырырга булдым.* Ф. Хөсни. **Кадерен белү** — тиешле бәя бирү. *Зиннәт теге вакытта Нәфисәнең кадерен белмәвенә күптән үкенә башлаган иде инде.* Г. Бәширов. *Ләкин кадрен белү кирәк — Яшь вакытлар тиз үтә.* Ә. Ерикәй. **Кадер китү (калмау)** — 1) сыйфат ягыннан начарлану, кыйммәте кимү. *Юган киемнең кадере китә;* 2) абруе кимү, бәясе төшү. [*Таһирҗан хәлфәнең*] *шәкертләр арасында кадере китте.* З. Һади. **Кадер киче, кичәсе** *дини* — уразаның егерме җиденче кичендә үткәрелә торган дини бәйрәм. *Безләргә кадер киче булды бу „төн“.* М. Гафури.

КАДЕРЛЕ *с.* 1. Ихтирам ителә торган, якын һәм яраткан; сөекле, хөрмәтле (кеше турында). *Шулай да син* [*әни*] *минем иң якын, иң кадерле кешем булганлыктан, ике арада илче йөртәсем килмәде...* [*диде Газиз*]. Г. Бәширов. *Газинур Александрны үзенең иң якын, иң кадерле дусты, туганы, коралдашы итеп саный иде.* Г. Әпсәләмов. || Көтеп алынган, хөрмәтле (кунак һ. б.). *Бүген кайта авылга иң кадерле кунаклар.* М. Җәлил. [*Нәгыймә*] *үзе дә, балалары да, бәйрәмчә киенеп, кадерле кешенең чәйгә чыгуын көттеләр.* Г. Кутуй. || Иркә, кадерләп торган. *Кадерле бала.* || Кадер-хөрмәт эчендә яшәгән. *Шәһибәк карт бай вакытында шундый кадерлерәк ялчы булып яшәгән.* Г. Ибраһимов.

2. Бик кирәкле, әһәмиятле, кыйммәтле (әйбер һ. б. турында). [*Китапларны*] *югалта, пычрата күрмә инде алайса, бик кадерле китаплар алар, улым.* М. Гали. *Әгәр менә хәзер үк Сәйфулла килеп кермәсә, бик кадерле бернәрсәсен югалтыр --- төсле тоелды аңа.* Ә. Еники.

3. *күч. шигъ.* Җылы хисләр белән, сагынып искә алына торган (истәлек һ. б. турында). *Ачык тәрәзәдән кергән төн һавасы иң кадерле, иң газиз истәлекләрне уятты.* Г. Бәширов.

4. Ин яхшы дип саналган (ин түрдәге, ин дәрәҗәле урын турында). *Ул рәсем дә* [*Хәят рәсеме*] *Михаил өстәленең иң кадерле урынына барып басты.* Ф. Әмирхан.

5. *и. мәгъ. тарт. форм.* **кадерлем.** Ярату, иркәләү һәм ихтирам хисләре белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Кил, акыллым, кил, кадерлем, күңелемә бәйрәм китер.* Ә. Ерикәй.

6. *рәв. мәгъ.* Бик нык карап, тәрбия белән. *Кадерле яшәү.*

КАДЕРЛЕЛӘНҮ *ф.* Кадерлегә әйләнү, кадере арту.

КАДЕРЛӘНҮ *ф.* 1. Хөрмәтләнү, сөелү, иркәләнү. *Бер дә әллә ничек түгел: гимназистка булып өйдәге бар кешегә кадерләнеп бозылып беткән.* Ф. Әмирхан.

2. Кирәклегә әйләнү, кадере арту (кемнең яки нәрсәнең). *Энемне ат башында йөрергә, мине печән җыярга чакыручылар күбәйде. Шулай итеп без кадерләнеп киттек.* М. Гафури.

3. Нәрсәне дә булса саклык белән генә тоту, файдалану. *Өстендәге кара кыска кием бик кадерләнеп йөртелә.* Г. Ибраһимов.

КАДЕРЛӘҮ *ф.* 1. Олылау, кадер-хөрмәт күрсәтү, ихтирам итү. *Аналарны кадерләргә, сакларга кирәк.* А. Шамов. | *рәв. мәгъ. — Без бит сине, әйбәт чәчүче дигән булып, кадерләп тоттык.* Г. Гобәй.

2. Кемне яки нәрсәне иркәләп, яратып тәрбия итү, үстерү, карау. [*Илдар:*] *Вакытлыча шул барып төшкән әбидә торам. --- Үз баласы кебек кадерли.* Т. Гыйззәт. *Җир юмарт ул, тик аны кадерләргә, хөрмәт итәргә генә кирәк.* Каз. утл. | *рәв. мәгъ.* [*Урта килен*] *хәлле ата-ананың бик көтеп алган, кадерләп үстергән ялгыз баласы иде.* Г. Ибраһимов.

3. *рәв. мәгъ.* **кадерләп.** Сак кына, саклык белән. *Шәйхаттар бабай янчыгын бәйләде дә кадерләп кенә чалбар кесәсенә --- салып куйды.* Г. Гобәй. [*Фуат*] *--- кыйммәтле чималны бик кадерләп алып кайтып җиткерә.* Ә. Касыймов.

КАДЕРСЕЗ *с.* 1. Кадере булмаган, кадер-хөрмәт күрми торган. *Эттән әрсез, чүптән кадерсез чаклар да була.* М. Хәсәнов. | *рәв. мәгъ. Революция тәмам җиңгәннән соң, Вәли бай да иленә кайтып кадерсез, хөрмәтсез яши башлый.* Г. Нигъмәти.

2. *күч.* Хурлыклы, яман дип саналган; данлыксыз. *Безнең илдә юк оятлы һәм кадерсез һичбер эш.* М. Җәлил.

3. Яраксыз, файдасыз, кирәксез (әйбер турында). *Акмаган сулар кадерсез, Файдасыз һәм кирәксез.* Ә. Ерикәй.

4. *сөйл.* Әдәпсез, тәрбиясез, тәртипсез. [*Әби Низами турында:*] *Фу, кадерсез!.. Моңа ни калган инде тагын?* Г. Ибраһимов. | *рәв. мәгъ. Кадерсез кылану.*

КАДЕРСЕЗЛЕК *и.* 1. Кадерсез булу сыйфаты, кадерсез булу хәле. || Кадерләп, карап тотмау, игътибарсызлык. *Кадерсезлектән тутыгып сына кайчак корыч та.* Мәкаль.

2. Начар мөнәсәбәт, түбәнсетеп, кимсетеп карау. *Безнең күргән кадерсезлекләрне бер әт тә күрмәс.* Г. Камал.

3. Әдәпсезлек, тәрбиясезлек. *Кешеләр күрсәткән кадер-хөрмәтнең бәясен тиенләп үлчәү үзе бер кадерсезлек булыр иде.* Сов. әд.

КАДЕРСЕЗЛӘНҮ *ф.* 1. Кадерсезгә әйләнү, кадере бетү.

2. Бәясе төшү, бәясен югалту.

3. Тәртипсезләнү, үзен әдәпсез тоту, затсызлану.

КАДЕРСЕЗЛӘҮ *ф.* 1. Хөрмәт итмәү, ихтирам итмәү. *Кадерсезләмә башымны, Мин кадерсез үсмәдем.* Җыр.

2. Бәясен төшерү, кадерен җибәрү.

КАДЕТ I: **кадет корпусы** — революциягә кадәрге Россиядә дворян уларын офицерлыкка хәзерли торган ябык урта хәрби уку йорты.

КАДЕТ II *и. тар. полит.* Революциягә чаклы Россиядә: конституцион-демократик партия дип аталган буржуаз контрреволюцион партия члены. *Кадет, эсер, меньшевик һәм милләтчеләрдән торган шәһәр Думасы, --- эшчеләрне гаепләп карар чыгарды.* К. Нәҗми. *Меньшевиклар, эсерлар, Советларның аяк-кулларын бәйләп, кадетлар ихтыярына --- тапшырдылар.* И. Гази.

КАДИМ *с. иск. кит.* 1. Прогресска дошман, искелекне яклаучы. [*Себер бае:*] *Кара син аны, үзе кадим булса да аптека тота икән.* Г. Камал.

2. Борынгы, әллә кайчангы, иске. *Кадим заманнардан калган.* □ *Бәет кечкенә чакта укыган бер кадим китабыннан иде бугай.* Г. Тукай. || Дини схоластикага нигезләнгән. *Шәкерт котырта дип, [Давытны] кадим мәдрәсәдән кудылар.* Г. Ибраһимов.

КАДИМГЕ *с. иск. к.* кадим 1. *[Мөселман отряды] кадимге казак белән сугышырга дип язылыр өчен кирәк.* Ш. Усманов.

КАДИМГЕДӘЙ *рәв. к.* кадимгечә. *Ике-өч ай үту белән, ул кадимгедәй бөтен эшләргә төшенеп алды.* Ш. Камал.

КАДИМГЕЧӘ *рәв.* Электәгечә, искечә, әллә кайчан булгандагы кебек. *[Шәрәф:] сап-сау эшләп йөрде, кадимгечә йөреп кайтты да шунда ук егылды. Бер сүз дә сөйли алмады.* М. Фәйзи.

КАДИМИ *с. иск.* 1. Борынгы, искедәге, әллә кайчангы. | *и. мәгъ. [Мәдинә] Бибиҗамал апаның кадимидән бирле саклап килгән --- тәлинкәсен төшереп ватты.* Ш. Хөсәенов.

2. *к.* кадимче. *Аның [музыкага булган] гыйшкын төбе белән аңлаган кадими бер хәлфә исә һәрвакыт: „Егетләр, менә Зыя белән музыка арасында нинди нисбәт! --- дип көлә иде.* Г. Ибраһимов.

КАДИМЧЕ *с. иск.* Искелекне яклаучы, прогресска каршы булган; реакцион. *[Г. Камал] „Безнең шәһәрнең серләре"ндә Печән базарының кадимче идеологларыннан көлә.* Г. Нигъмәти. || *и. мәгъ.* Искелек тарафдары, прогрессның чын дошманы; реакционер. *Кадимчеләребез үзләренең милләт файдаларын ничек аңлаганлыкларын, гыйлем вә мәгариф эшенә ни дәрәҗә мөнәсәбәтләрен бу Петербургка барып кайтулары белән бик яхшы күрсәттеләр.* Ф. Әмирхан.

КАДИМЧЕЛЕК *и.* Кадимчеләргә хас сыйфатлар, кадимчеләр карашы, идеологиясе һ. б. *Кадимчелеккә каршы көрәш.* □ *[Г. Тукай] тормышта, культурада кадимчелек бозыклыкларына каршы көрәшкә чыга.* Г. Нигъмәти.

КА'ДМИЙ *и. хим.* 1. Цинк рудасы составында була торган көмеш сыман ак төстәге йомшак металл.

2. Төрле төсмерле ясалма сары буяу.

КАДР I *и.* 1. Предприятие, учреждение, партия һәм профсоюз оешмаларындагы хезмәткәрләрнең хәзерлекле төп составы. *Инженер-техник кадрларның белемен күтәрү буенча институт каршында бер еллык курслар оештырыла.* Р. Ишморат. || *с. мәгъ. Гомерен станок янында уздырганлыгы әллә кайдан күренеп торган карт кадр эшчеләр дә Карасуда [Хәдичә өчен] ят, сәер күренешләр иде.* А. Расих.

2. *хәрби.* Хәрби частьларның тыныч вакытта да демобилизацияләнми торган даими составы. *Кадрдагы офицер.* || *с. мәгъ.* Кадрга мөнәсәбәтле. *[Солтан] үзенең фин сугышында булуын, аннан соң армиядә кадр хезмәтендә калуын --- сөйләде.* А. Расих.

Кадрлар бүлеге — предприятие яки учреждениенең эшче һәм хезмәткәрләрне эшкә алу, эштән азат итү белән шөгыльләнә торган бүлеге. *Кыш уртасында гына фронттан кайткан кулсыз майор заводның кадрлар бүлеге начальнигы булып эшли башлаган иде.* Ә. Еники.

КАДР II *и.* 1. Кинопленкадагы яки фотопленкадагы аерым рәсем, сурәт.

2. Кинофильмнан аерым бер күренеш яки эпизод. *Менә [экранда] кадр алмаша, башка күренешләргә юл ача.* Ж. Тәрҗеманов.

КАДРИЛЬ *и.* 1. Алты фигурадан торган бию (биючеләр кара-каршы басарга һәм сан ягыннан тигез булырга тиеш). *Кадриль бию.*

2. Шул биюнең музыкасы. *Сине дәртләндерер гарьмонлы җыр бу: Биерсең, бәлки, бу кадрильгә каршы.* Г. Тукай.

КА'ДРОВИК *и. сөйл.* 1. *хәрби.* Кадр хезмәтендә торучы гаскәри. *Галим, мөгаен, Кызыл Армиядә кадровик булып калыр.* Г. Әпсәләмов.

2. Тәжрибәле кадрлардан исәпләнгән эшче, белгеч. *[Славик] иртән берәр җайлы участок сайлап бирсен үзләренә һәм җиллерәк кадровик беркетсен.* Г. Гобәй.

КАДӘР *бәйл.* 1. Юнәлеш килеше белән: пространстводагы бер араның, хәрәкәтнең һ. б. икенче чик ноктасын билгеләү өчен кулланыла; чаклы, хәтле. *Сәгәди абзый да, Зөһрә апа да, күзләренә тулган яшьне яшерә алмый, басу капкасына кадәр Габдулланы озата бардылар.* Ә. Фәйзи. *Казанка елгасы тамагыннан башлап Бишбалтага кадәр вак таллар үсеп тора иде.* М. Гали.

2. Юнәлеш килеше белән: билгеле бер вакыт арасының ахыргы чик ноктасын билгеләү өчен кулланыла. *Гали абзый янында Газинур таңга кадәр утырырга да риза иде.* Г. Әпсәләмов.

3. Юнәлеш килеше белән: берәр нәрсәдән әлек, алдан булган эш-хәлне белдерә. *Сугышка кадәр мин бит нинди тракторист идем.* Р. Ишморат.

4. Юнәлеш килеше белән: нәрсәне дә булса тулысынча эченә алуны белдерә. „Бөтенләй", „тулысынча", „барысын да" дигән сүзләргә туры килә. *Мостафаның иреннәренә кадәр тузан сырышкан иде.* Ш. Камал. *Рабига беренче очрашуның барлык вак детальләренә кадәр хәтерли.* А. Шамов.

5. Күләм яки микъдар (чама) ягыннан чагыштырутиңләштерүне белдерү өчен кулланыла. *Аннан-моннан йолка торгач, кирәк кадәр өй җиһазы да табылды.* Г. Ибраһимов. *Килмәс идем, үзем кадәр алтын бирсә дә!* А. Алиш.

6. Берәр затта яки предметта нинди дә булса сыйфатның, үзлекнең, үзенчәлекнең югары дәрәҗәсен белдерә. *Минутлар нигә бу кадәр авыр, үзәк өзгеч булып үтәләр икән!* А. Шамов.

7. *-ган* формасыннан соң килгәндә: мөмкинлекнең чиген билгеләү өчен кулланыла. *Биби аягын булдыра алган кадәр йомшак басып йөри иде.* Ф. Әмирхан. — *Кулдан килгән кадәр тырышырбыз.* Ш. Камал.

КАДӘРГЕ *бәйл.* Берәр нәрсәдән әлек булган, алдан булган эш-хәлне белдерү өчен кулланыла. *Кайберләре исә үзләренең сугышка кадәрге күңелле тормышларын искә алдылар.* А. Әхмәт. *[М. Гафури] революциягә кадәрге татар хатын-кызларының язмышын „Кара йөзләр" повестенда көчле сурәтләде.* М. Җәлил.

КАДӘРЛЕ *бәйл. к.* кадәр. *Озак еллар буенча таптала торгач белүләнгән, шомарып беткән өстәл кадәрле зур ташка аягы тиюгә, Нәфисә нидер исенә төшкәндәй туктап калды.* Г. Бәширов.

КАДӘХ *и. иск.* Эчемлек эчә торган савыт; зур рюмка, бокал. *[Шәүлихан:] генерал Кауфман --- миңа һәрвакыт менә бу шигырьне укырга куша иде: Кадәхеңне мул тутырып, Күбекләнгән ялкын ширбәтен китер.* Т. Гыйззәт. — *Әгәр дә сез дөньядагы иң зур идеал өчен кадәх күтәрергә теләсәгез, рюмкаларыгызны кулларыгызга алыгыз!..* К. Тинчурин.

КАЕЗЛАМА' *и. диал.* Карт юкәнең тышкы тупас кабыгыннан чистартылган астагы кайрысы, өлеше. *Каезлама җәйгән арба.*

КАЕЗЛАУ *ф.* 1. Нәрсәнең дә булса тышкы кабыгын куптару, өске катлавын чистарту. *[Хәлим] аяклары каезламыйча, өсте ышкыламыйча ясалган тәбәнәк өстәл күрде.* Г. Гобәй. *Ул арада Мөхәммәтҗан бабай, каезлаган юкә кочаклап, урманнан килеп тә чыга.* М. Гали. || *куч. гади с.* Күп итеп, комсызланып ашау турында. *Кәҗә бер яшь кенә алмагачны рәхәтләнеп каезлый иде.* И. Гази.

2. *күч.* Бик нык кыйнау. *Әхмәт чанага утырган та, сулагай куллап чыбыркыны әйләндерә-әйләндерә, атны ныклап каезлый башлады.* Ш. Камал. *Егетнең аптыравына каршы, икенчеләре берәм-берәм кундыра, кабырга буйларын каезлый башлап, кыйнап ташладылар.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Талау, көчләп алу. *Тегермәндә кычкырып сөйләшкән өчен дә штраф сала башладылар. Каезлыйлар гына!* Ә. Фәйзи.

КАЕК *и.* Агачны чокып ясаган көймә. *Читтән Барый тавышы: „Чәнчелсен, бу каекка утырып йөрим дип, я батарсың“.* М. Фәйзи. *Улимагда дигәне кайчандыр аучы оночлар юан тирәктән чокып ясаган озын каек иде.* Г. Әпсәләмов.

КАЕКЧЫ *и.* Елга аша каек белән кешеләрне чыгаручы. — *Каекчы карт, тыңла суземне, җилкән белән озат кызымны!* М. Җәлил. *Каекчы көймәчегә юл бирер.* Мәкаль.

КАЕН *и.* Яфраклары йөрәк рәвешле, ак кайрылы агач. *Яңа гына үзалдына җилфердәтеп нәфис яфракларын ачкан яшел каенның очына [күке] килеп кунды.* Ә. Еники. ‖ *с. мәгъ.* Каеннан эшләнгән, каеннан ясалган. *[Хуҗа хатын] мич башыннан нечкәләп-нечкәләп телгәләнгән коры каен чыраларын алды да лампа урынына яндырып җибәрде.* Г. Ибраһимов.

Каен гөле — яфраклары каен яфрагына охшашлы, ак чәчәк ата торган агач сыман бүлмә гөле. *Менә бу — каен гөле. Күпьеллык гөл.* Г. Галиев. **Каен гөмбәсе** *бот.* — каен урманында үсә торган кара-көрән эшләпәле гөмбә. **Каен суы** — яз көне каеннан алына торган татлы су. *Менә бу кошлар сайравы да, татлы каен суы һәм яшел яфраклар исе дә --- һәммәсе дә [Зиннәткә] тансык, ул аларның һәммәсен дә сагынган иде.* Г. Бәширов. **Каен җиләге** — 1) ак чәчәк атып, хуш исле алсу-кызыл төстәге җиләк бирә торган үлән үсемлек; 2) шул үсемлекнең җимеше. *Нинаять, тау кашларында, чокыр-чакырларның кояшка караган битләрендә каен җиләкләре мәмрәп пешәләр.* А. Гыйләҗев.

КАЕНАГА, КАЕНАГАЙ *и.* Иргә карата хатынның абыйсы һәм киресенчә. — *Каенагай белән бәҗәй озаклады, мин әйтәм.* Т. Гыйззәт.

КАЕНАНА *и.* Хатынга (иргә) карата ирнең (хатынның) әнисе. *Каенана белән килен бер-берсен ана белән кыз төсле якын күрәләр иде.* С. Рафиков. *Солтан, Суфияга өйләнеп бераз вакыт торганнан соң ук, каенанасының шикләнеп үзен күзәтүен тойды.* А. Расих.

Каенана теле *сөйл.* — кактус төренең исеме.

КАЕНАПА *и. сөйл. к.* каенигәч. *Каенапа белән каенсеңел [Рәүфәне] беренче көнне үк дус итеп күрә башладылар.* А. Шамов.

КАЕНАТА *и.* Хатынга (иргә) карата ирнең (хатынның) әтисе. *Каената белән киявнең калыплары бер күренә.* К. Тинчурин.

◇ **Каената туфрагы** — каенана-каената йорты, кияү йорты. *Шулай Гөлбану ата йортыннан каената туфрагына аяк басты.* Г. Ибраһимов.

КАЕНЕ *и.* (Хатынга карата) ирнең әнесе. *Нәфисә каенесенең җитез ишә-ишә, дулкыннар өстендә тирбәлгәләп, Идел уртасына кереп китүен карап торды да үз печәнлегенә кайтырга чыкты.* Г. Бәширов.

КАЕНИГӘЧ *и.* (Хатынга карата) ирнең апасы.

КАЕНИШ *и.* **1.** (Иргә карата) хатынның әнесе. *Җизни ничектер башын артка ташлап, каенишенә өстән һәм кырын карап сүзләрне теш арасыннан чыгарып җибәрде.* Ә. Фәйзи. — *Җизнәңә агитациянең кирәге юк, каениш.* Р. Ишморат.

2. (Хатынга карата) ирнең кыз һәм ир туганнары. *Уңган киленнең усал каенана тырнагы, каенишләр теле астында ничек изелүе --- әсәрдә киң рәвештә күрсәтелгән.* Г. Нигъмәти.

КАЕНЛЫК *и.* Каен үсә торган урын; каен урманы. *Тигез кыр уртасында кечкенә ап-ак каенлык күренә иде.* Ә. Еники.

КАЕНСАР *и. сөйл. к.* каенлык. *Каенсарда ак каеннар Шаулый җилләр искәндә.* З. Мансур. *Сәмәкәрнең суы тирән, Ике ягы каенсар.* Җыр.

КАЕНСЕҢЕЛ *и.* Хатынга карата ирнең кече кыз туганы. *[Йөзлебикә] күз кырые белән генә каенсеңелесенә карап, авыр сулап куйды.* Г. Бәширов.

КАЕРУ *ф.* **1.** Беркетелгән, ныгытылган нәрсәне икенче бер әйбер ярдәмендә урыныннан куптару, чыгару. *[Нигъмәтҗан] берүзе түбәгә менеп такталарны әллә каяк каерып алып бәрде.* Ә. Фәйзи. ‖ Әйбернең бер башын яки ягын кире якка юнәлтү, бору. *Көчле җил аның муенына ураган шарфының очларын, бүрегенең озын колакларын артка каера.* Г. Әпсәләмов. *Бер хатын алъяпкычына төрле яфраклар тутырып, очларын биленә каерып бәйләгән.* М. Фәйзи.

2. Аяк, кул, баш һ. б.ларны нормаль булмаган торышка китереп бору, имгәтү. *Степанов башта чалгы сабын тотып алды, малайның кулын каерды.* А. Гыйләҗев. — *Юлда нәрсәдәндер атым өректе, егылып билемне каердым, — диде [Азым-әкә].* Г. Ибраһимов.

3. Зур күләмле итеп актару, куптару (туфрак, балчык һ. б.). *Шәйхаттар бабай, чи калган җирдә туктап, сабан төрәне каерып салган кәсләрне аягы белән буразнага сыпырып төшерде.* Г. Гобәй. ‖ *рәв. мәгъ.* **каерып.** Зур-зур алым белән. *Ида ике куллап ишкәкләргә тотынды да, Сәгыйть кебек каерып ишмәкче булып, бар көченә селтәнергә тотынды.* Н. Фәттах. *Чи тиресне каерып-каерып арбага ыргыту җиңел булмады.* И. Гази.

4. Юлдан читкә бору, борылу. — *Тот та аермадан сулга каер, авылның аргы башында мин үзем каршы алырмын.* Ф. Хөсни.

5. *күч.* Кемнең яки нәрсәнең интересын күздә тотып, мәсьәләне яки фикерне шул якка юнәлтү; шуны яклау, кайгырту. *[Юлдашев] я проекттан бер карыш та чыкмау ягын каера, --- я мәсьәләне хәл кылуны кирәгеннән артык суза.* С. Рафиков. *Бер-бер артлы чыгып сөйләүчеләр бары да бер якны каералар, сүз куешкандай, бер җырны җырлыйлар.* А. Расих.

6. *күч.* Мул итеп, тиешеннән артык алу. *Ул акчаны күбрәк каерырга ярата.* Х. Җәмил.

7. *күч.* Башкару, эшләү. — *Я, әхмәт, үзең ни эшләр каерасың? Һаман союзда эшлисеңме әле?* Ш. Камал.

Каерып алу — 1) тартып алу, кемнең дә булса кулыннан көч белән алу. *Я, әйт әле, әйтче, [немецларның], Канлы куллар белән каерып алып, Күкрәгеңә кыскан балаңны Танк асларына ыргытуын Күрер көнгә калыйкмыни без?!* Ф. Кәрим; 2) *к.* каеру 6. *[Тегге кеше], имән бармагын кәкрәйтеп, берсенең маен каерып алды да, аны иреннәрен чәпелдәтә-чәпелдәтә тәмләп, шунда ук икенчесенә сузылды.* Г. Бәширов. **Каерып ачу (ишекне, капканы һ. б.)** — киң итеп, төбенә кадәр ачу. *Шәрифҗан арбадан төште дә, җил капканы каерып ачып, атны ишек алдына алып керде.* И. Гази.

КАЕРЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* каеру (1—3 мәгъ.). *Канатлары каерылган бөркетләр нишли алсыннар — һавага күтәрелә алмыйлар.* А. Шамов. *Кыз, сулга каерылып, әле яңарак кына салынган тирән эз белән урман ешлыгына атлады.* Э. Касыймов.

2. Утырган яки басып торган хәлдә гәүдәне артка таба нык бөгү, артка киерелү, борылу. *Сыртланов,*

каерылып, әлеге кешеләр китәргә тиешле якка карады, ләкин эзләгән кешесен күрә алмады. Ш. Хөсәенов.

3. *рәв. мәгъ.* **каерылып.** Киерелеп, киң селтәнеп. *Кулларындагы камчылары белән каерылып суга-суга, котырган эт кебек, өстебезгә ташландылар.* А. Шамов. *Менә ул, туктап, чалгысын кайрап алды да тагын каерылып-каерылып чабарга тотынды.* И. Гази.

◇ **Каерылып уну** (игеннәр турында) — бик нык уну, мул уңыш бирү. *Быел җәй яңгырлы килде. Шуңа күрә игеннәр каерылып уңды.* Ш. Маннур.

КАЕШ *и.* **1.** Озынча күн тасма. [*Әт*] *борылды да, елый-елый, үзе җигелгән чананың каешын чәйнәргә кереште.* Г. Гобәй. [*Нигъмәтҗан*] *өстенә брезент тужуркасын, башына каскасын киеп алды да стенадагы каешка кыстырып куйган балтасына үрелде.* Ә. Фәйзи. ‖ *с. мәгъ.* Каештан эшләнгән, каештан ясалган. [*Фазылҗан агай*] *атын туарга та, кулына ат куалый торган каеш чыбыркы тотып, тавышсыз-тынсыз гына өйгә керде.* Ш. Камал.

2. Күннән һ. б. нәрсәдән ясалган билбау. *Бил каешын ычкындырып, ашый-ашый, әбисенең уңганлыгын мактап бетерә алмый.* Ә. Еники.

3. *тех.* Әйләнү хәрәкәтен бер шкивтан икенче шкивка тапшыру өчен күннән яки тыгыз, нык материалдан озын итеп эшләнгән, очлары бер-берсенә тегелгән киң тасма. *Әйләнер-әйләнмәс тора Машина каешлары.* Җыр. *Триерның кай җирендәдер каешы ычкынып мы шунда, орлык чистартучылар беразга эштән туктадылар.* С. Рафиков. ‖ Багаж бәйләү өчен махсус ясалган тасма, бау. *Юл каешы алдым.* Г. Тукай. [*Сәмигулла*] *--- пөхтәләп, нык итеп, каеш белән бәйләнгән төенне чиштерде.* Ф. Әмирхан.

КАЕШЛАНУ *ф.* **1.** Берәр нәрсә тиеп ышкылудан, орынып торудан шомару, ялтырау. [*Җамали абзый-ның*] *башында колакчын бүрек, бүрек астыннан каешланып беткән түбәтәй чите күренеп тора.* А. Әхмәт. *Көзге юллар каешланып ялтырап калды, алардан ат һәм үгезләр җигелгән арбалар көнетөне Идел буена агылды.* Г. Бәширов. ‖ Озак вакытлар ятып яки җилләп кибү, кату (ипи һ. б.). *Артельщик солдат --- күгәреп, каешланып беткән кара икмәк сохарие өләшеп чыкты.* М. Гали.

2. *күч.* Шомару, остарып китү, өйрәнеп җитү; **кыюлану.** *Председатель, күптән инде һәртөрле шелтәдән каешланып беткән утызлар тирәсендәге егет, бик өлгер җавап бирде.* Ә. Еники. *Малайлар, тагын да каешлана төшеп, Сәфәргалигә якын ук килделәр.* Ф. Хөсни.

КАЕШЧЫ *и.* Каеш яки каештан төрле нәрсәләр эшләүче. *Каешчы Нигъмәтҗан белән хатыны Бибиәсма эшләп биргән ияр ләбаса ул!* Ә. Фәйзи.

КАЗ *и.* Озын муенлы ак яки соры төстәге эре су кошы. *Кыр казы. Ата каз. Ана каз.* □ *Озын муеннарын сузып, саф-саф булып тезелешеп, казлар кайтып киләләр.* А. Әхмәт. ‖ Ашамлык итеп хәзерләнгән каз ите. *Мәҗлескә аш-су, шулпа, бәлеш, каз, үрдәк, ширбәт --- биргәндә дә Мәрхәбәнең ярдәменнән башка үтмәде.* Г. Ибраһимов.

Каз тәпие *бот.* — *к.* каз үләне. **Каз юасы** *бот.* — кыр суганы. **Каз юлы** — аяз төннәрне күктә гади күзгә якты полоса (юл) булып кына күренә торган йолдызлар тупланышы. *Күк йөзен тутырып, йолдызлар кабына. Баштан башка каз юлы сузыла.* Г. Гобәй. **Каз өмәсе** — көз көне казлар сую уңае белән үткәрелә торган өмә, сый йоласы. *Миңлебикә кодагый бүген каз өмәсе уздыра.* К. Нәҗми. **Каз үләне** *бот.*— су буйларында үсә торган сары чәчәкле үсемлек. *Каз үләне белән өртелгән урамнарда бернинди хәрәкәт юк.* А. Расих.

◇ **Каз йөреше** — күкрәкне киереп йөрү турында. **Каз тәне** — тәндә салкыннан яки артык дулкынланудан, кинәт куркудан барлыкка килгән вак кына төерчекләр. *Елгада көндезләрен су шундый җылына, иртәдән кичкә хәтле коенсаң да „каз тәне“ булмый.* И. Гази.

КАЗА *и.* Афәт, зур зыян, бәхетсезлек. *Уракка-мазарга төшкәләгәнче, каза күргән хуҗалыкларны торгыза башларга кирәк иде.* А. Гыйләҗев. *Үзе белән бергә алып китә* [*яңгыр*] *Корылыкның авыр казасын.* Ә. Ерикәй.

◇ **Каза кылу** — берәр нәрсәне ниндидер сәбәп белән вакытында үти алмыйча, икенче вакытта үтәү. *Кышкы челләдәге кебек чатлама суыклар башланды, һәм, шул арада игеннәр сугылып, никрутлар* [*күңел ачуларны*] *каза кылырга тотындылар.* Г. Ибраһимов. **Казага калу** — вакытында үтәлми калу. *Бик күп предприятие һәм учреждение җитәкчеләре --- кыш буена казага калып килгән эшләрен башкару өчен Казанга агыла башладылар.* М. Әмир.

КАЗАК I *и.* **1.** XV — XVII йөзләрдә крепостной крестьян, холоп һәм шәһәр ярлылары арасыннан рус дәүләтенең чикләренә (Дон, Җаек, Запорожьега) качып киткән ирекле кеше.

2. XVIII йөзләрдә Россиянең Дон, Кубань, Терек, Оренбург кебек өлкәләрендә махсус гаскәри частьларда хезмәт иткән өчен җирдән льготалы файдаланган хәрби сословие вәкиле. Шушы катлау вәкилләреннән торган хәрби частьта хезмәт итүче рядовой. *Эшчеләрне, бигрәк тә стачкалар вакытында, фабрикантларның кысуларына түзә алмыйча, эшне туктаткан вакытларда, полиция һәм казаклар кыйный иде.* М. Җәлил.

3. Элеккеге хәрби өлкәләрдә туып үскән крестьян. *Дон казаклары.*

КАЗАК II [қазақ] *и.* Казахстан ССРда яшәүче һәм төрки телләрнең берсендә сөйләүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе, вәкиле. *Казак балалары. Казак акыннары.*

КАЗАКИ *и. иск.* Тегелеше белән озын камзулга охшаган, ләкин җиңле һәм кечерәк кенә утыртма якалы өске кием. [*Мәрданша бабайның*] *башында киез эшләпә, өстендә бишбилле казаки, кулында озын гына таяк иде.* Г. Гобәй.

КАЗАКИЛЫК *с.* **1.** Казаки тегү өчен билгеләнгән. ‖ Казакига җитәрлек булган. *Ике казакилык материал.*

2. *и. мәгъ.* Казаки тегү өчен кирәкле материал. *Зөягә барып, ике улына да әче-тышы берочтан сары төстәге киҗеле казакилык алып кайтып, авылның Гайсә тегүчегә биреп, аларны бишбилләп, кызыл төймәләп тектереп тә алды.* М. Гали.

КАЗАЛАНУ *ф.* Казага дучар булу, казалы булу.

КАЗАЛАУ *ф.* Үтәлми калган эшне икенче вакытта башкару. [*Хөршидә:*] *Мин дә --- калдырган намазларымны казалап алыйм әле.* С. Баттал.

КАЗАЛЫ: казалы булу — каза күрү, нәрсәдән дә булса мәхрүм булу (мәсәлән, мал үлү һ. б.). [*Мочтак:*] *— Хәлләр шәптән түгел! Казалы булдым, атым үлде.* Т. Гыйззәт.

КАЗАМАТ *и. иск. к.* төрмә. *Казаматның ишек алды җәй булса да кыш кебек; Казаматта без ятабыз читлектәге кош кебек.* Бәет.

КАЗАН *и.* **1.** Аш пешерү һәм су кайнату өчен кулланыла торган асты ярым түгәрәк чуен савыт. *Менә чәйнек астына үт та ягылды һәм балыклар да юылып казанга салынды.* М. Җәлил.

2. *техн.* Судан пар алу яки башка максатлар өчен кулланыла торган зур ябык савыт. [*Газиз Рәхимә-*

гә:] — *Киттек. Өченче казанның ходка китүен мин өч тапкыр гудок биреп белдерермен.* А. Әхмәт.

3. *сөйл.* Су төбендәге яки җир өстендәге зур булмаган тирән чокыр.

4. *күч.* Нәрсәнең дә булса үзәге, иң күп тупланган урыны. [*Фәйзи*] *чыкырдаган меньшевиклар казанында кайный.* Ш. Камал. *Схоластик моназара казанына, башка күпләр арасына, аталары тарафыннан Йосыфҗан белән Давыт та китереп ябылалар.* Г. Ибраһимов.

Казан аслык — махсус вакланган утын. [*Газинур*]— *Д безнең якта* [*авылда*] *әниләр казан аслыкка да аптырый,* — *диде.* Г. Әпсәләмов. **Казан асты** — учак. *Камилә торып, су китереп, сыер савып кергәнче,* [*Мәрьямнең*] *казан асты ягылып, бәрәңгесе пешерелеп, самовары куелып өлгергән була.* Ә. Еники. **Казан асу** — казан астына ут ягып, аш пешерә башлау. [*Гөлбикә*] *чәйдән соң, казан асып, ит салды.* Г. Ибраһимов. **Казан кунасы** — казан капкачы. *Килене казан кунасын ачты, пар томаны --- кечкенә өйнең һәр почмагын томалап алды.* С. Рафиков.

◇ **Казанында кайнату** — тәрбияләү, теге яки бу фикерне, идеяләрне сеңдерү. [*Революция*] *иске тәрбиядә үскән кешеләрне дә, үзенең казанында кайнатып, үзгәртеп чыгара.* А. Шамов.

КАЗАНДАШ *и.* Элекке мәдрәсәләрдә бер казаннан файдаланучы, бер казаннан ашаучы. *Казандаш булачак шәкертләрнең миңа сәерсенеп, бераз читләштереп караулары сизелеп тора иде.* М. Гафури.

КАЗАНЛЫК *и. геогр.* Тирән сөзәк чокыр.

Казанлык розасы — Болгариядә кыйммәтле май алу өчен үстерелә торган роза.

КАЗАНУ *ф.* Үзенең хезмәте, үз-үзен тотышы белән берәр мөнәсәбәткә, исемгә һ. б. ирешү. [*Гөлсем апага*] *баланың мәхәббәтен казанырга кирәк иде.* Г. Гобәй. [*Шәймәрдәнев*] *гади мехны асыл мехка әйләндерүчеләрнең берсе булып, зур исем казанды.* Р. Ишморат.

КАЗАНЧЫ *и.* Пар казаннары белән эш итүче белгеч. *Дгерҗе депосында казанчы булып эшләгән кешегә кадрлар бүлегеннән салкын цехта эшләде дип белешмә җибәргәннәр.* Каз. утл.

КАЗАНЫШ *и.* Зур көч, тырышлык куеп яулап алынган уңыш; эшнең югары нәтиҗәсе. [*Татар операсы*] *бөтен дөнья югары музыка культурасының казанышларын үзләштерү, өйрәнү нигезендә туды.* М. Җәлил.

КАЗА'РМА *и.* Хәрби частьларны урнаштыру өчен махсус бина. *Кичен ятар алдыннан* [*солдатларны*] *казарма ишек алдына чыгарып стройга тезделәр.* М. Гали. ‖ Революциягә кадәр фабрикалар, промыселлар һ. б. ш. карамагындагы эшчеләр тулай торагы. *Николай бер иптәше Федор белән неводчылар казармасына киттеләр.* Ш. Камал.

КАЗА'ЧИЙ *и. сөйл.* Казаклар гаскәрендәге рядовой. *Тик фронтка китә торган атлы казачийларның җырлары гына ара-тирә* [*Җаек*] *шәһәренең тынлыгын бозгалады.* Ә. Фәйзи.

КАЗАЧОК *и.* **1.** Бию исеме.

2. Шул биюнең көе. *Казачокка бию.*

КАЗАЯК *и. бот.* **1.** Күпчелек очракта сары чәчәк ата торган агулы үлән үсемлек. *Арба эзе араларына зәгыйфь шушшма казаяклар, бака яфраклары сырышкан юл башланды.* А. Гыйләҗев.

2. Көлтәләрне вакытлыча өю рәвеше.

КАЗАЯКЧАЛАР *и. бот.* Казаяк, чалма баш һ. б. чәчәкләр кергән семьялык атамасы. *Казаякчалар семьялыгы.*

КАЗГАНУ *ф.* Тырышып, көч-сәләтне кызганмыйча эшләү. *Хезмәтеңнең, тир түгеп казгануларыңның нәтиҗәсен күрмәүдән дә авыррак нәрсә юктыр.* М. Хәсәнов.

КАЗЕИН *и.* Сөт составындагы аксым матдәсе (буяу, пластмасса, җилем, лак һ. б. ясау өчен киң кулланыла). *Кәҗә сөтенең аксымы (казеины) җиңелрәк үзләштерелә.* Ф. Мостафин.

КАЗЕМАТ *и. махс.* **1.** Артиллерия һәм авиация утыннан саклану, орудиеләр һәм пулеметлар кую һәм сугыш кирәк-яракларын саклау өчен бетон корылма. *Ут эчендә калган җимерек фортка дошман атакага ташлана, немецлар вал һәм казематларга бәреп керәләр.* Э. Касыймов.

2. Революциягә кадәр политик тоткыннарны ябу өчен бер кешелек камера.

КАЗЁНКА *и. иск.* Революциягә кадәрге Россиядә: аракы сатыла торган кибет. *Без* [*аракыны*] *үз акчабызга казенкадан барып алабыз.* М. Фәйзи.

КАЗЁННЫЙ *с. сөйл.* **1.** Казнаныкы, казнага караган. [*Кызылармеец:*] *Әйберләрне дә үзебез белән алыйк. Казенный нәрсәләрне калдырып йөрү ярамас.* Г. Камал. ‖ Казна исәбенә бирелә торган. [*Нуруллин Рабигага:*] *Степаныч төзәтеп биргән ботинкаң тузмаганмы әле?* — *Юк. Мин бит хәзер казенныйны киям.* А. Шамов.

2. *күч.* Формаль, бюрократларча. *Эшкә казенный мөнәсәбәт.* □ *Үзен прогрессистлар арасында саналганга, газета мөхәррирләренә ачуланып казенный хатлар яза торган чиновниклар --- һәммәсе шул мирзалар арасыннан чыккан фруктылар бит.* Ф. Әмирхан.

КАЗИНО *и.* Комарлы уеннар йорты; шулай ук Көнбатыш Европа илләрендә шәһәр читендәге һәм курортлардагы ресторанлы күңел ачу урыны.

КАЗНА I *и.* **1.** Дәүләтнең акча, җир, азык продуктлары яки башка байлыклары җыелмасы; дәүләт милке. *Казна ашаган казалы булыр.* Мәкаль.

2. Шушы байлыклар иясе буларак дәүләт һәм шулай ук байлык, мөлкәт белән идарә итә торган дәүләт учреждениесе. *Алар икесе дә йөз процент казнага эшлиләр.* К. Нәҗми. [*Шәмгун карт*] *казнадан ярмасын, онын, итен, балыгын, маен алып кайтты.* А. Шамов.

3. Байлык, хәзинә; акча. *Җир астында казна бар, Көн-төн анда казыналар. Шахтерлар, егетләр, Гөрселдәтеп-гөрселдәтеп, Ташкүмерне чабалар.* Ш. Камал. *Михнәтҗ чигеп тапкан бер тәңкә тиген килгән казнадан яхшырак.* Мәкаль.

КАЗНА II *и.* **1.** Мич астындагы куышлык һәм шул куышлыкны каплаган агач кыса; нигез. *Мин бая мич казнасыннан бер тимер таптым.* Т. Гыйззәт. *Мичнең казналары куелып, стеналары өелә башлады.* Г. Ахунов. ‖ Сәке йөзлеге. *Ул --- трубкасын авызыннан алып, сәке казнасына кагып --- кесәсенә салды.* М. Гафури.

2. Теш урнашкан урын, теш оясы, теш төбе. *Мулла теш казналарын күрсәтеп елмайды.* И. Гази.

КАЗНАЛЫК *и.* Тешләр урнашкан бит сөяге. *Аскы теш казналыгы. Өске теш казналыгы.*

КАЗНАЧЕЙ *и.* **1.** Берәр учреждение, җәмгыять, оешманың акча һәм кыйммәтле нәрсәләрен саклаучы. — *Таныш булыйк,* — *диде ул, Хәсәнне үз янына чакырып.* — *Бәлки, ишеткәнсездер, милли Шура казначие Хизбулла Кадермәтевне.* К. Нәҗми.

2. Гаскәри частьларда: ашамлык-эчемлек, киемсалым, акча кабул итүче һәм аны өләшү эшләрен башкаручы кеше.

КАЗНАЧЕ'ЙЛЫК *и.* Казначей вазифасы. *Шәһәр башлыгы Дьяченко бу эшкә риза булган, әмма управада казначейлык эшен алып баручы гласный Борһан Муллин --- каршы килгән.* Ә. Фәйзи.

КАЗУ *ф.* 1. Көрәк һ. б. ш. нәрсә белән җирне йомшарту. *Җир казу. Бакча казу.* □ *„Илшат“ һәм „Ватан“ пионерлары чи калган җирләрне казырга керешеләр.* Г. Гобәй.

2. Туфрагын, балчыгын чокып чыгарып, уенты ясау. *Кое казу. Баз казу. Канау казу.* □ *Тау буенда Хәйдәр балалар белән чокырлар казып йөри иде.* Г. Бәширов.

3. Җир астыннан нәрсәне дә булса чокып чыгарып жыю. *Мин, туган, ике ел Себердә алтын казып торганым бар, өч ел Урал тауларында тимер казыганым бар.* Г. Коләхметов. *Бәрәңге казу вакытында миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә туры килмәде.* Г. Тукай.

4. Нәрсәне дә булса чоку, тырнау. *Кутырны казу.* □ [*Ат*] *аяклары белән җирне казыды, үрә торды, хәтта нуктасын да өзде.* А. Шамов. *Илһам чакырып, тырнак белән Казый-казый өстәлен, Бераз уйлап торды да ул Шул шигырьне өстәде.* М. Җәлил. ‖ Артык нәрсәләрдән чистарту максаты белән колак, борын, тешләрне чоку. [*Рәфгать:*] — *Һәдия, беләсеңме бу абый кем? — дигән сорауны бирде дә үзе, гадәтенчә, борынын казый башлады.* А. Әхмәт. *Беркөн* [*Корбангали карт*], *аштан соң каз каурые белән тешләрен казый-казый, Фәйзигә карап:— Кузьма Крючков хәзер кайда, беләсеңме? — диде.* Ш. Камал.

5. *күч.* Төпченү, тикшерү; *к.* казыну 3. [*Ярамаган урыннарга баруы*] *юк-барны казып йөрүче адәмнәр тарафыннан хәзрәткә җиткерелде.* Г. Ибраһимов.

Казып чыгару — 1) берәр төрле максат белән үткәндә булган эш-хәлне яңадан кузгату, искә төшереп сөйләү; 2) үткәндә эшләнгән жинаятьнең эзенә төшү.

КАЗУАР *и. зоол.* Төньяк Австралия һәм Яңа Гвинеяда яшәүче страуслар отрядыннан булган йөгерүче эре кош.

КАЗУИСТ *и. махс.* Суд практикасында катлаулы, буталчык эшләрне оста чишүче юрист.

КАЗУИ'СТИКА *и.* 1. *махс.* Төрле очракларга карата гомуми юридик закон статьяларын куллану.

2. *күч.* Ялган яки шикле положениеләрне исбат итүдә осталык, тапкырлык.

КА'ЗУС *и.* 1. *махс.* Суд практикасында катлаулы һәм буталчык эш.

2. *күч. сөйл.* Көтелмәгән, очраклы хәл, гадәттән тыш вакыйга. *Инде хәзер көтмәгәндә яңа казус!* А. Расих.

КАЗЫГЫЧ *и.* Казу өчен булган әйбер, корал. *Канау казыгыч. Теш казыгыч.*

КАЗЫЙ *и. тар.* Шәригать законнары буенча хөкем итүче рухани. *Эш бик зурга китсә, казыйга хөкемгә барырга туры килә.* М. Гафури.

КАЗЫЙЛЫК *и. тар.* Казый вазифасы. *Мулла никах, талак эшләрен карый, казыйлык итә, туганнарны, үлгәннәрне, никахланганнарны яза.* Г. Тукай.

КАЗЫК *и.* 1. Бер башы очланып, җиргә утыртыла торган кыска колга. [*Бикбулат*] *Тимерине юри санга алмыйча, яңадан казык кагарга тотынды.* Г. Бәширов.

2. *сөйл.* Иң түбән билге — берле билгесе (мәктәптә). *Кара аны, егет, укытучы ишетеп үзеңә казык утыртып куймасын.* Г. Гобәй.

Казык теш *анат.* — 1) кискеч һәм кечкенә урт тешләр арасындагы теш (кешедә һәм имезүче хайваннарда). *Мин --- [абыстайның] аслы-өсле селкенеп торган ике казык теше генә калган авызының ачылып ябылганын кызыксынып карап тордым.* М. Гали. 2) авыз куышлыгыннан тышкы якка чыгып торган зур теш (кабан дуңгызында, филдә һ. б. кыргый хайваннарда).

◇ **Казык кагу** — йорт, шәхси хуҗалык булдыру. *Сезгә дә, Шакир, үз казыгызны кагар вакыт житкәндер, шәт.* Ә. Еники. **Казык төсле (кебек) тору** — хәрәкәтсез, тик тору. [*Нәсимә Хәмидәгә:*] *Нәрсә казык төсле кадалып торасың?* Ш. Камал. **Казыкка утырту** *иск.* — җәзалау төре.

КАЗЫЛДЫК *с.* Борынгы дәверләрдә яшәгән яки үскән, хәзер жир кабыгының катламнарыннан казылып табылган (хайван һәм үсемлек турында). *Казылдык кәлтә. Казылдык үсемлек.*

КАЗЫЛМА I *и.* 1. Юлдагы сикәлтә, чокыр. *Көзге пычрак урманның юлы начар: казылма да, батканлык та мазар.* Г. Толымбай.

2. Махсус казылган тирән чокыр, канау. *Ничә сәгать инде --- орудиеләрнең көйдергеч сулышы Кәҗә бистәсе дамбасы буйлап килүче отрядларны чокырларга, казылмаларга ышыкланырга мәҗбүр итте.* К. Нәжми.

КАЗЫЛМА II *с.* 1. Казып алына, чыгарыла торган. *Казылма күмер.* ‖ *и. мәгъ.* Жир астыннан казылып алынган, табылган нәрсә. *Файдалы казылмалар. Археологик казылмалар.*

2. *к.* казылдык. *Казылма үсемлекләр.*

КАЗЫЛЫК *и.* 1. Атның түш ите. *Кунак хатын Мәрхәбә үзенең төенчеген чиште, иң элек кызыл киҗеле ашъяулык, аннан пешкән зур казылык, майлы күмәч --- алды.* Г. Ибраһимов.

2. Өйдә хәзерләнгән колбаса. [*Миләүшә*] *өстәлдән пычакны алып китеп, зур савыт тутырып, тәгәрмәчләп киселгән казылык китерде.* М. Хәсәнов.

КАЗЫЛЫКЧЫ *и.* Казылык хәзерләүче, казылык ясау остасы. *Җирән биягә атланган күк фәсле кешенең казылыкчы Хәйрулла икәнен белгәч, Сөләйманның аңа карап эче катып көләсе килде.* К. Тинчурин.

КАЗЫМА *и. диал. к.* лом. *Без --- иртәдән кичкә хәтле көрәкләр, казымалар белән юл төзәтеп, юл рәтләп йөридер идек.* Ш. Камал.

КАЗЫНУ *ф.* 1. *күч.* Озак маташу, мыштырдау. *Ни шайтаныма шулкадәр озак казыналар дип уйлады* [*казак иптәшләре турында*]. И. Гази.

2. Актарыну, эзләнү. *Казына торгач мич төбеннән әллә нинди бик зур ике бакыр акча да килеп чыкты.* Г. Гобәй. | *күч. Без татар халык музыкасының да йөз еллар буе үскән байлыгы өстендә --- ныклап казынмый һәм эшләми торып --- пролетариат музыкасын үстерә алмабыз.* М. Җәлил.

3. *күч.* Житешсезлекләр, кимчелекләр эзләү, төпченү. *Дөрес, ревизия --- озаграк һәм тирәнрәк казынса, тотып судка бирерлек жинаятьләрне дә тапкан булыр иде.* Ә. Еники.

КАЗ-ҮРДӘК *жый.* и. Казлар, үрдәкләр һ. б. кошлар. *Басма өстендә Каз-үрдәк.* Жыр.

КАЙ *а.* 1. *к.* кайсы 1. *Ә соң шахтер хисе кайда, кай жырыңның кайсы юлында?* Һ. Такташ. — *Кай жирең авырта, балам?* М. Гафури.

2. *к.* кайбер. *Хәлим, --- әнисенең кай көннәрдә аш пешерергә дә вакыты булмаганны хәтерләп, эндәшми калды.* Г. Гобәй.

Кай ара(да) — 1) кайчак, кайвакыт. — *Була, кай араларда бик авыр чаклар була.* Р. Ишморат. *Жил каты итеп исә, кай ара ботаклар белән шаяра.* А. Алиш; 2) берәр нәрсәнең тиз үтәлүенә гажәпләнүне белдерү өчен кулланыла. *Кай арада өч ай ярым вакыт үтеп тә киткән.* Г. Әпсәләмов. **Кай рәвешчә** — *к.* ничек. *Табигый юлы табыла алмагангамы, кай ноктадан, кай рәвешчә керешергә идеге беленеп житмәгәнгәме, теге эчтәге зур дәрья ташып чыгып, дөньяны басып та ташламады.* Г. Ибраһимов. **Кай таба** — берәр нәрсәнең яхшылыгын, шәплеген мактаганда әйтелә. — *Улының аягындагы читеге кай таба!*

Ә. Фәйзи. **Кай тирәдә** — теге яки бу эшнең торышы, үтәлеше дәрәҗәсен сорау өчен кулланыла: ничек, ни хәлдә. *Жалованье кай тирәдәрәк соң, Гомәр абзый?* Ф. Әмирхан. — *Я, синең эшләр кай тирәдә, Әлфия?* Г. Бәширов.

КАЙБЕР *а.* Арадан берничәсе. *Кайбер аеруча салкын төннәрдә агачлар шарт-шорт итә, әйтерсең мылтык аталар.* Г. Әпсәләмов.

КАЙБЕРӘҮЛӘР *и.* Кайсылары; аерым кешеләр. *Күрәсең, [Нәфисәгә] бик ачык булган нәрсәләр дә кайберәүләр өчен куе томан икән әле.* Г. Бәширов. *Кайберәүләре шахмат тактасы янына утырдылар.* А. Әхмәт.

КАЙВАКЫТ *рәв.* Кайчакта, вакыт-вакыт, ара-тирә, кайбер вакытта. *Кайвакытларда тавышын ишеткәч, йөрәгем „жу" итеп китә.* А. Шамов. *Якуб, яшьләрнең сөйләшүләрен тыңлап, елмаеп, кайвакыт үзе дә сүзгә катышып, су буенда уйланып утырды.* И. Гази.

КАЙВАКЫТНЫ *рәв. к.* кайвакыт. *Йөрәгемә кадап кайвакытны Авыр сүзләр әйтә усаллар.* Б. Рәхмәт.

КАЙВАКЫТТА 1. *а. к.* кайчан. [*Нәгыймә:*] *Соң, ипташлар, үзегез уйлап карагыз: ястү намазыннан кешеләр кайвакытта чыгалар?* Ш. Камал.

2. *рәв. к.* кайвакыт. *Кайвакытта диңгез тып-тын ята.* М. Гафури. *Без әле әниләребезне дә, апаларыбызны да сагынабыз, хәтта кайвакытларда балаларча зарланып та алабыз.* А. Шамов.

КАЙГЫ *и.* 1. Тирән психик кичереш, рухи газап; хәсрәт; *киресе:* шатлык. *Җамали белән Камали, кат-кат сөйләшеп, икәү тирән уйда, авыр кайгыда утырдылар.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Кайгы белән бәйләнешле, кайгыга караган. *Кайгы маршы. Кайгы флагы.* □ *Кайгы нуры күренә йөзендә.* Һ. Такташ.

2. Авыр тәэсир итә торган вакыйга, хәл; бәхетсезлек, бәла-каза. *Каты яшенле яңгыр, боз, иген сугылу, мал кырылулар белән дә багланган кебек, җәйдә чыккан кояш та күп вакытлар авылга кайгы салгалый.* Г. Нигъмәти.

3. Берәр нәрсәне үтәп чыгу, башкару турындагы уй, борчу; мәшәкать. *Хәллерәк йортларда кунак каршы алу, бал әчетү, пешерену-төшерену кайгысына керештеләр.* М. Гали. *Арышны суктың, ахры, күршә? — дйе, сугып салдык, Габдерүш дус, бер кайгы китте.* Ф. Бурнаш.

4. Интерес, мәнфәгать. *Әмма ил кайгысы бөтенесеннән дә көчле, илнең иминлеге барыннан да газизрәк икән.* Г. Бәширов. [*Мортазинга*] *халыктан аерылдың, халык кайгысыннан бигрәк үз кайгыңны кайгыртасың, --- диделәр.* Ә. Еники.

◇ **Кайгы басу** — бик зур кайгы килү, күп кайгылар килү. *Күлләгәсе төсле шул табутның Кайгы басты минем күңелне.* М. Җәлил. **Кайгы йоту** — тышка чыгармыйча эчтән генә кичерү. [*Зәйнәп:*] *Ах, әни, бу көннәрдә минем никадәр йөрәгем кайнаганын белсәң иде, нинди кайгылар йоткаңымны белсәң иде, кызганыр идең.* Ф. Әмирхан. **Кайгы күрү (чигү)** — кайгылы булу, кайгы кичерү. *Кайгы чигәргә ник болай соңга калдым икән?* Г. Толымбай. **Кайгы салу** — кайгы китерү, кайгыга төшерү. *Көтмәгәндә кайгы салды безгә бу көндә фәләк [язмыш], дй, сөекле яшь шагыйрькәй! Син югалдың иртәрәк.* М. Гафури. **Кайгы төшү (берәүнең башына)** — кайгы килү. *Хәлим башына берәр кайгы төшсә, --- аның өчен яшерен көенде [Гөлгенә].* Г. Гобәй. **Кайгыга бату (калу, сабышу, төшү)** — кайгы кичерү, хәсрәтләнү. *Син нәрсә бу хәтле кайгыга баттың?* Ш. Усманов. *Нигә [ул] кайгыга сабышкан, Нинди кайгы-сагыштан?* М. Җәлил. **Кайгыга салу (төшерү)** — нинди дә булса сәбәп белән кайгылы, борчулы итү. — *Тыныч башымны кайгыга салыр хәлем юк, — дип уйлады [хатын].* Г. Ибраһимов. *Галимә апа вакыйгасы һәммәбезне дә тирән кайгыга төшерде.* М. Гафури.

КАЙГЫЛАУ *ф. сир. к.* кайгырту (2, 3 мәгъ.). *Үз көнеңне үзең күреп, үз кайгыңны үзең генә кайгылап яши башлау [көтә алда].* Ш. Хөсәенов.

КАЙГЫЛЫ *с.* Кайгысы булган, кайгыга дучар булган, кайгы кичерүче. *Кайгылы ананың бу сүзе мине бөтен кан тамырларыма кадәр тетрәтте.* А. Шамов. || Кайгы белән тулы, борчулы. *Кайгылы көннәреңдә якыннарың янда булса, җаныңа җиңелрәк була.* Г. Гобәй. || Кайгы белдергән, кайгы чагылдырган. *Йосыф --- Һаҗәрнең агарган йөзенә, эчкә батkан кайгылы кара күзләренә карый.* К. Нәҗми. *Ләкин кайгылы иде, Сагышлы иде синең җырларың.* Һ. Такташ. | *рәв. мәгъ. Зәйнәп, кайгылы гына түбән карап, кулындагы кәгазь кисәген бөтереп утыра.* Ф. Әмирхан.

Кайгылы митинг — үлгән кеше истәлегенә багышланып, күмәр алдыннан үткәрелә торган митинг.

КАЙГЫРТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* кайгыру 1. [*Үз авылыңның] урамнарына килеп керү — --- [Габишне] шатландыра, юк, аннан көчлерәк итеп кайгырта.* Ф. Кәрим.

2. Берәр нәрсәнең артыннан йөрү, хәстәрен күрү. *Сабир абзый Сәйфуллинны үз улы шикелле бөтен кирәк-яракларын кайгыртып, аталарча киңәшләр биреп, --- озатып калды.* Ә. Еники.

3. Кемгә яки нәрсәгә карата кайгыртучанлык, игътибарлылык күрсәтү. *Әмма ипташларенең аны үз әниләре кебек кайгыртулары Мәүлихага бу авыр көннәрне җиңеп чыгарга көч бирде.* Г. Бәширов. — *Чын урманчы, — диде [Карп Васильевич], урманны кисү турында гына түгел, аны үстерү турында да кайгыртырга тиеш.* Г. Әпсәләмов.

КАЙГЫРТУЛЫ *с.* Кайгырту булган, кайгырту чагылган.

КАЙГЫРТУЧАНЛЫК *и.* 1. Кайгыртучан булу сыйфаты.

2. Кайгырту, игътибар күрсәтү. *Сезнең тарафтан миңа шундый тирән игътибар һәм сизгер кайгыртучанлык күрсәтелүгә мин чиксез ныk шатланам.* М. Җәлил.

КАЙГЫРУ *ф.* 1. Кайгы кичерү. *Газизә төн караңгысында кайгырып елап утыра.* Ш. Камал.

2. Берәрсе яки берәр нәрсә турында борчылу, уйлану. *Син кайгырма, карчыгым, ялгыз гына булмам, табылыр кешеләр.* Г. Минский. [*Ирбулат:*] — *Әсин шулай да кайгырма, апа, Хәмит абый хат язмаса да, исән-сау.* Р. Ишморат.

КАЙГЫРЫШУ *ф.* Бергәләп кайгыру (күп кешеләр турында). *Әнкәле-уллы алар шулай бик озак кайгырыштылар.* И. Гази.

КАЙГЫ-САГЫШ *җый. и.* Төрле хәсрәт, сагынулар. *Безнең беребез авыр сугышларда Утлар аша үтте кан түгеп. Беребез көтте кайгы-сагышларда, Төннәр йокламыйча интеген.* Ә. Ерикәй.

КАЙГЫСЫЗ *с.* 1. Кайгысы булмаган, кайгысы юк (кеше). *Кайгысыз кое суы эчеп тә тазара.* Мәкаль.

2. Борчусыз, тыныч (тормыш, яшәеш турында). *Кайгысыз тормыш кичерү.*

3. Ваемсыз, исе китмәүче (кеше турында). || *рәв. мәгъ.* Ваемсыз рәвештә, исе китмичә. *Биби өсте ярым ачык килеш бер дә кайгысыз, кулларын җәеп йоклап ята.* Ф. Әмирхан.

КАЙГЫСЫЗЛЫК *и.* Кайгы, мәшәкать юклык; ваемсызлык.

КАЙГЫ-ХӘСРӘТ *җыйк. и.* Кайгы һәм хәсрәтләр. *Кайгы-хәсрәтләрне шатлык алмаштырды.* Г. Гобәй.

КАЙДА *а.* **1.** Кемнең яки нәрсәнең урынын белергә теләп сораганда кулланыла. *Сажидә апасы кайда, нишли микән хәзер?* Ә. Фәйзи. *Мин сулар сибәм тугайда, Тау бөркетем, син кайда?* Ф. Кәрим. || Нәрсәнең дә булса булмавына гажәпләнү, көенүне белдерә торган сорау-өндәү җөмләләрдә кулланыла. *Кайда инде ул яхшы тору!* Һ. Такташ. *Китәр алдыннан аерыла алмыйча таңнар аттырган сөйкемле Зиннәт кайда да, аның вәгъдәсе кайда?* Г. Бәширов.

2. *рәв. мәгъ.* Кайсы урында, нинди урында. [*Остаз-бикәнең*] *хәзер кайда икәне мәгълүм түгел.* Г. Ибраһимов. || Юклык формасындагы фигыль янында *да* кисәкчәсе белән килеп „бер урында да“, „һичкайда да“ мәгънәләрен аңлата. *Укыган кешеләр кайда да хур булмыйлар.* М. Гафури.

3. *рәв. мәгъ. дә, менә* алмашлыклары белән килеп, мәсьәләнең асылын, предмет һәм аның төп урынын аңлата һәм шуңа игътибарны юнәлдерә. *Менә бит мәсьәлә кайда?* Ш. Камал. *Шул вакыт кинәт Якубның исенә төште: әнә кайда күргән иде бит ул аны.* И. Гази.

4. *мөн. сүз.* Баш җөмләдәге *шунда* сүзе белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен урын җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Кайда ныклы тәртип урнаштырыла, шунда эш, яхшы сыйфатлы итеп, вакытында башкарыла.* Ф. Хөсни. *Тиз китик без шунда, кайда җәелгән ямь-яшел кырлар.* Г. Тукай.

5. *рәв. мәгъ.* Җөмләнең тиңдәш кисәкләре алдында кабатланып килә һәм „бер урында“, „икенче урында“ дигән мәгънәне аңлата. [*Гөлгенә*] *кайда үрмәләп, кайда йөгереп ярдан менеп китте.* Г. Гобәй.

6. *кис. функ.* Хәбәре исем фигыль белән белдерелгән тойгылы җөмләләрдә эш-хәлнең үтәлүе мөмкин түгеллеккә басым ясый. *Кайда монда килү, өйгә дә көчкә генә кайтып җиттем.* Г. Камал. *Кайда ул болай читтә кунарга китә алу!* М. Гафури. || Раслау, хуплау төшенчәсен көчәйтеп килә. — *дәбәт булмаган кайда ул! — диде председатель Сөләйманов та.* Ә. Еники.

КАЙДАГЫ *а.* Кемнең яки нәрсәнең кай яктан, нинди урыннан булуын сораганда кулланыла. *Сез кайдагы хатын соң?* М. Гафури.

КАЙДАДЫР *а.* Ниндидер билгесез урында, кайсыдыр якта. *Кайдадыр су гына челтерәп ага.* И. Гази. *Кайдадыр, якында гына --- команда тавышы яңгырады.* Ф. Хөсни.

КАЙДАН *а.* **1.** Кемнең яки нәрсәнең нинди урыннан, кайсы яктан икәнен сораганда кулланыла. — *дәтем, бу бүрекне кайдан алдың?* М. Җәлил. || Нинди чыганактан, кайсы яктан, кемнән, нәрсәдән. *Бу яшь егеткә кайдан килгән бу кадәр моң?* Г. Әпсәләмов. *Мохтар чыккән башлы сөлгенең кайдан килеп чыкканлыгына инде тәмам төшенә язды.* Ш. Камал.

2. *рәв. мәгъ.* Кайсы урыннан, кайсы баштан, яктан. *Эшне кайдан башларга белмичә торганда ишек ачылды һәм чемоданнар күтәреп ике кеше килеп керде.* Г. Минский.

3. *мөн. сүз.* Баш җөмләдәге *шунда* сүзе белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен урын җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. — *Безнең мәңгелек тынычлыгыбызны бозасыз, нишләп болай шаярасыз, җибәрмибез, кире борылыгыз, кайдан килдегез, шунда китегез, — диделәр.* А. Алиш.

КАЙДАНДЫР *а.* Ниндидер билгесез урыннан. *Кайдандыр су тегермәненең салмак кына гөжләве ишетелеп тора.* Ф. Хөсни. *Кайдандыр җыр яңгырый.* Г. Әпсәләмов. || Ниндидер чыганактан, кемнәндер. [*Колын турында*] *кайдандыр ишетеп, безнең Сафа бабай да ак сакалын җилбердәтеп килеп керде.* Г. Ибраһимов.

КАЙЗЕР *и. тар.* Рим һәм Германия империясендә император исеме һәм шул титулга ия булган кеше. *Украина белән Белоруссия исән, Советлар Россиясе дә исән, ә кайзер тәгәрәп ята.* И. Гази.

КАЙМА *и.* Нинди дә булса әйбернең, тукыманың һ. б. төсе, бизәге яки материалы белән аерылып торган чите, кырые. [*Хәмидә:*] — *Алар --- аннан кала чите каймасыз мамык шәл --- сорыйлар.* Г. Камал. || *күч.* Нәрсәне дә булса сызык кебек уратып алган әйбер. *Түшәмнәрдә уңалмый торган кыйммәтле путал каймалар белән уратылган художестволы табигать күренешләре сурәтләнә.* Ш. Камал.

Кайма тоту — *к.* каймалау.

КАЙМАК *и.* **1.** Сөтнең өстенә җыела торган куе, майлы өлеше. *Сөт өстенә каймак утырган.* □ *Сөтнең каймагын җыябыз да сыегын башкаларга калдырабыз.* Т. Гыйззәт. || Сөт өстеннән җыелып алынган яки сепаратордан аерылып чыккан куе, майлы масса. *Өстәл уртасында берничә савыт белән тозлы кәбестәсе, кыяры, куе каймагы --- тора.* Ә. Еники.

2. *күч.* Нәрсәнең яки кемнең дә булса иң әйбәте, иң яхшысы. *Безнең Арча ягында сабан туеның каймагы, иң күңелле өлеше --- икенче көнне башлана.* Г. Бәширов.

КАЙМАКЛАНУ *ф.* Сөт өстенә каймак утыру, каймак җыелу.

КАЙМАКЛЫ *с.* **1.** Каймагы мул, күп (сөтнең сыйфаты турында); каймагы аерып алынмаган. *Мин --- каймаклы салкын сөтне эчәргә тотындым.* А. Шамов.

2. Каймак салынган; каймак кушылган. *Бәлки әле* [*әби*] *каймаклы катык белән дә сыйлап чыгарыр.* И. Гази.

КАЙМАЛАНУ *ф.* Кайма тегелү, кайма тотылу яки башка төстән кайма ясалу. *Шарфның очлары ак мамык белән каймаланган булуы һәм аның бер башында ниндидер чигешләр барлыгы күренде.* М. Әмир. || *күч.* Уратып алыну. *Ватан үзенең батыр улларын каршылаганда, Фатыйма кайгы карасы белән каймаланган хат алды.* Г. Минский.

КАЙМАЛАУ *ф.* Кайма тегеп чыгу. *Яулык читен каймалап чыгу.* || *күч.* Уратып алу, әйләндереп алу. *„Җилкәй“ моторлы көймәне --- журналистлар дачасын каймалаган тыныч аулак култыктан Иделгә --- алып чыкты.* А. Гыйләҗев.

КАЙМАЛУ *ф. диал.* Җилфердәү. *Менә Мәскәү --- мәгърур Кремле — Башнясында Кызыл байрагы --- Дулкынлана җилгә каймалып.* М. Җәлил.

КАЙМАЛЫ *с.* Кайма тотылган, кайма тегелгән яки башка төс белән читләнгән. [*Садыйк*] *камзул кесәсеннән кызыл каймалы зур гына ак яулык чыгарып күзләрен сөртте.* Ш. Камал. || *күч.* Кайма кебек нәрсә белән уратылган, каймага охшашлы. *Керфекләре кара, ә күзләре якты соры иде, шунлыктан кара каймалы булып күренәләр иде.* Ә. Еники.

КАЙМАН *и. зоол.* Үзәк һәм Көньяк Америкада яшәүче крокодил төре.

КАЙМЫГУ *ф.* Урыныннан чыгу, урыныннан күчү, таю (организмдагы буыннар турында). *„Аяксыз калдым!“ — дип уйлады [Андрюша], ләкин бәхетенә тик сул аягы гына каймыккан булып чыкты.* К. Латыйпов.

КАЙМЫКТЫРУ *ф.* Тайдыру, тайдырып чыгару. *Гөлшаһидә, җайсыз басып, аягын каймыктырган иде.* Г. Әпсәләмов.

КАЙНАГА *и. к.* каенага.

КАЙНАНА *и. к.* каенана.

КАЙНАР *с.* **1.** Яңа пешерелгән яки кайнатылган, суынып өлгермәгән. *Бүген дә кайнар бодай кабартмасы янында бер тәлинкә йомырка урын алды.* Г. Бәширов. *Ул арада өстәл өстенә кайнар чәй дә китереп куйдылар.* А. Шамов. || Эссе, кызу; кызган, пешерә торган. *Кешеләрнең йөзенә кайнар җил килеп бәрелде.* Ә. Фәйзи. *Ә директор чишенеп ташлады да Кайнар комга килеп сузылды.* М. Җәлил.

2. *күч.* Дәртле, ялкынлы, ярсулы. *Мостафа үзе дә тиз кабынучан, кайнар йөрәкле кеше иде.* К. Нәҗми. || Кызу, тиз кабынучан. *Миңнулла шикелле бер кайнаррагы чәчрәп чыкты.* И. Гази. || Хисләрнең тирәнлеге белән аерылып торган; көчле тойгылар белдергән. *Кайнар сәлам. Кайнар теләк.* □ *Һәйкәлнең өстенә һәм ян якларына чуеннан коеп кайнар сүзләр язылган иде.* Э. Касыймов. — *Син үзеңнең кайнар мәхәббәтең, шәфкатьле йөрәгең белән җылытмаган булсаң, бәлки, мин хәзер яшәмәгән дә булыр идем.* Р. Ишморат. || Киренке, кискен, кызу. *Беренче кайнар чыгышлардан кызып киткән атмосфера хәзер сизелерлек дәрәҗәдә сүрелә төште.* Ә. Еники.

Кайнар аш — җылы ашамлык. [*Полковник Илдарский*], *сугышчыларның әле һаман да кайнар аш ашамауларын белгәч, тыл начальнигын бик каты кыздырып алды.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Кайнар баш(лы)** — тәвәккәл һәм кыю. *Иптәш Сафин кебек кайнар башларга тулысынча юл куйсаң — бәхетсезлек көт тә тор.* С. Рафиков.

КАЙНАРЛАНУ *ф.* **1.** Кайнар хәлгә килү, эсселәнү, кызу; температурасы күтәрелү. *Примуста озак торып, Җамалиның суы артыграк кайнарланып киткән булырга кирәк.* М. Гали.

2. *күч.* Дәртләнү. *Ындыр табагы берьюлы җанланып китте. Кайнарланып эшкә тотындылар.* Г. Бәширов.

КАЙНАРЛАТА *рәв.* Кайнар килеш, кайнар көенчә, суытмыйча. *Чәйне кайнарлата эчү зарарлы.*

КАЙНАРЛАТУ *ф. к.* кайнарлау. *Һәркайчан кыздырса көн диңгез йөзен кайнарлатып, „Бу“ булып күккә оча да „су“ булып җиргә төшә.* Ш. Бабич.

КАЙНАРЛАУ *ф.* Кайнар итү, температурасын күтәрү, җылыту.

КАЙНАРЛЫЙ *рәв. к.* кайнарлата. *Ишмай карт шикелле, өйрәне кайнарлыйрак ашарга ярата торган кешеләр --- ашчыларны орышып-орышачаклар.* Ш. Камал.

КАЙНАРЛЫК *и.* Кайнар булу сыйфаты, хәле.

КАЙНАТА *и. к.* каената. [*Шәмгун:*] — *Шулайрак, хатын белән бала-чагаларны төяп кайнаталарга кунакка җибәрдем.* Т. Гыйззәт.

КАЙНАТМА *и.* Берәр дару үләне яки җиләк-җимеш һ. б. салып махсус кайнатылган су (дәвалау өчен). *Карчык --- әзерләп алып килгән әрем кайнатмасын көчләп эчерде.* Г. Ибраһимов.

КАЙНАТУ *ф.* **1.** Нәрсәне дә булса җылытып кайнау хәленә китерү. [*Хәмдия:*] — *Әллә мәтрүшкә чәчәге кайнатып биримме, улым?* Р. Ишморат. *Уңган хатын кар өстендә казан кайната.* Мәкаль. || Билгеле бер формага китерү, билгеле бер үзлек бирү өчен берәр нәрсәне кайнап торган сыеклыкта тоту. *Кер кайнату.* □ *Фәүзия җиңги --- байтак май әзерләде, әремчекләр кайнатып куйды.* М. Гафури. *Юаларны кайнатырга салгач, куна такталары бушар.* Ә. Фәйзи. || Куу, кудырып әзерләү (самогон). [*Габишнең*] *этисе үзе самогон кайнатып сатып ята торган кеше.* Ф. Кәрим.

2. *күч.* Баш, ми, йөрәк, кан һ. б. ш. сүзләр янында килеп, ярсыту, үч, ачу тудыру яки башка берәр хис, кичерешләрне көчәйтеп җибәрү мәгънәсен бирә. — *Шәйхи мәзин --- минем битемә төкерә-төкерә, йөрәгемнең ярасына тоз салып кайнатты.* Ш. Камал. *Соңгы вакытларда башын, йөрәген кайнаткан зәһәрләр тагы* [*Мостафаның*] *бөтен тәненә таралып, көйдерә башлады.* Г. Ибраһимов.

КАЙНАУ *ф.* **1.** Бик нык кайнарлау аркасында пар ясалып күбекләнү, быгырдау (сыеклык турында). *Самовар куйдым күмерсез, Кайнап чыгар күрерсез.* Җыр. || Ыгы-зыгы килеп тору. *Ындыр гөрли, машина өстендә куе тузан бөтерелә, ындыр кайнап тора.* Г. Бәширов. *Колхоз канцелариясе кайный.* М. Гали.

2. *күч.* Ярсып, ашкынып тору, көчәю (хис, тойгы һәм кичерешләр турында). *Шул чагында йөрәкләрдә Ярсу, дәрт кайный.* Ә. Еникәй. || Ашкынып, ярсып, гөрләп, кызып китү (берәр эш һ. б. турында). [*„Үрге әрәмәлек“тә*] *апрель башыннан ук эш кайнап китте.* Ш. Камал.

3. *күч.* Кайнашу (1 мәгъ.), гөж килеп тору. *Перронда халык кайный.* Г. Әпсәләмов.

4. *күч.* Озак вакытлар бергә эшләү, бергә булу, аралашу. [*Доцентның*] *ничә елдан бирле инде русча лекцияләр укуына карамастан, эштә дә һәрвакыт рус арасында кайнавына --- карамастан, һаман рус телен бозып, акцент белән сөйләшүе Солтан өчен бик сәер тоелды.* А. Расих. || Нинди дә булса вакыйгаларга турыдан-туры катнашу, зур эш алып бару. *Сыйнфый көрәшнең эчендә кайнау Маркс һәм Энгельсска бөтен дөньяны бер күзлектән карарга мөмкинлек бирде.* М. Абдрахманов.

КАЙНАШУ *ф.* **1.** Тәртипсез хәрәкәт итү, буталу; гөж килеп тору. *Күк йөзен томалап өлгергән каракучкыл болытлар тау-тау булып берсе өстенә берсе актарылды, болганып, кайнашырга тотынды.* Г. Бәширов.

2. Маташу, булышу, берәр эш белән мәшгуль булу. *Ләкин, кызның көймә тирәсендә сокланырлык оста кайнашканын күреп,* [*Илдар*] *ачкан авызын япты.* Г. Гобәй. *Беркөн бер солдат үтеп барышлый Гапсаттар абзыйларда кунып чыккан, — диде Фатыйма, учак янында кайнашып.* И. Гази.

3. *күч.* Аралашу, катнашу, кемнәр белән дә булса бергә булу, шул тирәдә чуалу. *Кайтып төшкән көннәрдә ячейка белән, яшьләр белән кайнашып, ничектер иркен бер вакыт таба алмадым.* Г. Ибраһимов.

4. *к.* кайнау (2 мәгъ.). *Мин картайдым хәзер, хәлдән тайдым, Тик йөрәгем һаман кайнаша.* М. Гафури. *Куркыныч уйлар килеп баскач, иректсез баш бөгәм, Эчтә хәсрәт кайнашып ташкач, өзлексез яшь түгәм.* Ш. Бабич.

КАЙНОЗОЙ: кайнозой эрасы *геол.* — җирнең геологик тарихында иң яңа эра; өченчел, дүртенчел дип исемләнгән ике чорга бүленә, соңгысына хәзерге дәвер дә керә.

КАЙРА *и. зоол.* Төньякта яши торган акчарлакларга охшаш диңгез кошы.

КАЙРАГЫЧ *и. сөйл. к.* кайрак.

КАЙРАК *и.* **1.** Пычак, бритва, чалгы һ. б. кораларны үткенли торган таш. *Хисам ишек алдындагы сулы кайракта балта чарлый иде.* А. Расих.

2. *күч.* Пешкән ипидә күпермичә тыгыз булып каралып, ялтырап торган урын (гадәттә ипинең аскы өлешендә була).

КАЙРАКЛАНУ *ф.* **1.** *к.* каешлану (1 мәгъ.). — *Сакал-мыек кырып, чәч алдырып торырга вакыт юк әле, Насыйр абзый, — диде Шөгаеп, үзенең чуалып

як-якка таралган чәчләрен кайракланып беткән кәләпүше астына тыгып. М. Гали. *Күп эштән [Ишморат бабайның] тиресе кайракланып беткән.* Сәйфи-Казанлы.

2. *күч.* Пешмәү, кайрак (2 мәгъ.) хәлендә калу.

КАЙРАУ *ф.* Кайрак яки шундый ташка тотып, корыч яки тимердән эшләнгән әйбернең йөзен чыгару, үткенләү. *Дхмәт чарда чалгы кайрый.* М. Фәйзи.

КАЙРАУЛЫ *с.* Кайралган, үткенләнгән. *Минем балта белән пычкы кайраулы, кузгалсыннар гына, миннән эш тормас, — ди икенче күрше.* И. Гази.

КАЙРАУЧЫ *и.* Кискеч коралларны кайрау, үткенләү белән шөгыльләнүче. — *Пычак кайрыйм, бритва!— дип кайраучы кычкыра.* Г. Коләхметов.

КАЙРЫ *и. бот.* Агач кабыгы. *Без кайрылары купкан берничә төп юан-юан агачлар янына килеп туктадык.* Г. Галиев. *Тополькләрдән баллы кайры исләре аңкый.* Ш. Камал.

Кайры балы — *к.* төчлегән. **Кайры корты (коңгызы)** *зоол.* — *к.* кабыкчы. **Кайры тун (толып)** — иләнгән тиредән тегелгән тышсыз тун. *Шулай да [Рәхмәтулла картның] иң яратып эшләгән нәрсәсе кайры тун тегү иде.* М. Гали.

◇ **Кайры каезлау** — кирегә сукалау, икенчегә бору. — *Син кайры каезлап маташма, улым, яме.* К. Тинчурин.

КАЙЧЫ *а.* 1. Күпләр арасыннан берсен белү өчен сораганда кулланыла. — *Габдуллажан, син кайсын, Хисами кызынмы, Бәдри кызынмы алырга риза буласың?* Г. Камал. — *Бабай, син кайсы авылныкы буласың?* Т. Гыйззәт.

2. *к.* кайбер. *Берничә кыз баскычка чыгып, кайсылары тәрәзәне ачып карап калалар.* М. Фәйзи. *Кайсы вакытта ул йөзен минем йөземә якын ук китерә, кайсы вакытта ераграк тота иде.* Ф. Әмирхан. || Тиңдәш кисәкләр алдыннан кабатланып килеп, „берсе“ һәм „икенчесе“ дигән мәгънәне аңлата. *Кайсы коча, кайсы кулны кыса, Чәчәк суза кайсы кулыма.* Ә. Исхак.

3. *мөн. сүз.* Баш җөмләдәге *шул* яки *шуны* сүзе белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен аергыч яки тәмамлык җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә...* Г. Тукай. *Ул ---, [елкының] кайсы кирәк булса, шуны бер ташлауда корыкка эләктерергә өйрәнгән адәм иде.* Г. Ибраһимов.

Кайсы кая — төрлесе төрле якка, төрлесе төрле җиргә. *Укытучылар кайсы кая таралып беткән чак иде.* Г. Бәширов.

КАЙСЫБЕР *а. к.* кайбер. *Кайсыбер усалрак кызлар „елак малай“ дип мине үртәргә керештеләр.* М. Гали.

КАЙСЫДЫР *а.* 1. Кемдер. *Ял иткәч, үзе үк сикереп торыр әле, — дигән булды кайсыдыр.* И. Гази.

2. Ниндидер (билгесез нәрсә турында). *Бөтенләй якында гына нәрсәдер „лап“ итеп төште — күрәсең, давыл кайсыдыр өйнеңме, сарайныңмы түбәсен кубарып ташлады.* Г. Әпсәләмов.

КАЙТАВАЗ *и.* 1. Кире кайтып ишетелгән тавыш. *Җырымны җырладым урманга, Кайтаваз яңгырады томанда.* Г. Афзал. *Мәдинәнең аянычлы тавышы йокыга талган урам буйлап китте дә кайтаваз булып яңгырады.* Ш. Хөсәенов.

2. *күч.* Җавап буларак барлыкка килгән, кабатланган күренеш турында. *Рус тукучыларының Иваново һәм Орехово-Зуеводагы стачкаларына кайтаваз булып Бөя башы һәм аның тирәсендәге Акчуриннар фабрикаларында забастовкалар, стачкалар оешкан.* Сов. әд.

КАЙТАДАН *рәв.* Тагын, яңадан, кабатлап, икенче тапкыр. [*Гыйльми карчык*] *әле генә әнигә сөйләгән сүзләрен Хәмидә әбигә дә башыннан ахырына чаклы кайтадан сөйләп чыкты.* М. Гафури.

КАЙТА-КАЙТА *рәв.* Кабатлап, кат-кат. *Мондый яхшы репродукция таба алганы өчен җизнигә кайта-кайта күңелемнән рәхмәт укып куям.* Н. Исәнбәт.

КАЙТАРА-КАЙТАРА *рәв.* Кабатлап, кат-кат. [*Кияү*] *мәҗлестәге бөтен кешегә --- тату тормыш теләүләре өчен кайтара-кайтара рәхмәтләр укыды.* А. Шамов.

КАЙТАРГЫЧ *и. махс.* Яктылык, җылылык нурларын, электрлы магнит дулкыннарын кире кайтару җайланмасы. *Яшенле яңгыр вакытында, --- яшен кайтаргычлар тирәсендә дә тормаска кирәк.* Азат хатын.

КАЙТАРМА *с.* Кайтарылып бөкләнеп куела торган. *Кайтарма якалы күлмәк. Кайтарма җиң.* □ *Муллаңың өстендә кайтарма якалы тун.* Э. Касыймов.

Кайтарма күпер — күтәртелеп куела торган күпер. *Кайтарма күперләр аркылы гына әчкәре узарга мөмкин булуы Мусаны бик гаҗәпкә калдырды.* Ш. Маннур. **Кайтарма тун** — мехы тышка салдырылып тегелгән тун. *Тимерче Гәрәй бүген дә өстенә озын кайтарма тунын кигән, башында күн бүрек.* М. Хуҗин.

КАЙТАРУ *ф.* 1. Кайтып китәргә кушу, боеру, рөхсәт бирү; кире борып җибәрү. *Газинур тагы да сөйләшергә әзер иде, ләкин Сабир бабай аны кайтарып җибәрде.* Г. Әпсәләмов. || Нинди дә булса хәлдә кире озату. — *Ник турсайдың? Малайлар кыйнап кайтардылармы әллә? --- Шундый сүзләр белән каршы алдылар өйдә Габдулланы.* Ә. Фәйзи.

2. Алган әйберне кире бирү, хуҗасына тапшыру. *Архипов ордерны карагач, һидияткә кайтарып бирде.* Ш. Камал. [*Ханым*] *минем исемә төшерде: — Укып чыккач, [дәфтәрләрне] үземә кайтарып бирерсез...* Ф. Хөсни.

3. Тотылган чыгым кадәр файда алу яки файда китерү. *Д син, акыллы кеше булсаң, үзең бел, күр, туйдыр син аны, сыйла. Ат ул сиңа биште белән кайтарыр.* Р. Ишморат. *Дрәм китмәс безгә бирелгән көч, Кайтарырбыз аны эш белән.* М. Гафури.

4. Берәр эшкә, хәрәкәткә, сүзгә һ. б. шундый ук итеп җавап бирү. *Сез мине үз итәсез, сезнең игелегезне кайтарырга кулымнан килмәгәнлектән мин оялам.* Ш. Камал. *Сәлимә баш селкеп аның сәламен кайтара.* Ф. Әмирхан.

5. Берәр нәрсәне яки хәлне яңадан булдыру, әлекке хәлгә, торышка китерү. *Рәис карлыккан тавыш, көчле кыңгыравы белән бик озак акырынганнан соң гына мәҗлесне яңадан тәртипкә кайтара алды.* Г. Ибраһимов. [*Командирның кушу тоны*] *Нуруллинны үз хәленә кайтарды.* А. Шамов.

6. Берәр нәрсәне алып кайту, китерү. [*Мортаза:*] — *Тыныч бул, Закирыч, безнең егетләр ул корычны кайтарып та җиткергәннәрдер инде.* Р. Ишморат.

7. Баш һәм өс киемнәренең берәр өлешен кирегә, өске якка таба бөкләп, күтәреп кую. *Хәнифә ханым --- башындагы ак батист яулыгын маңгаена төшереп борынгыча артка кайтарып бәйләгән.* Ә. Еники. [*Малик*] *бүре толыбының якасын кайтарып салды.* И. Гази. || Төрле япма, пәрдә һ. б. ларның читен бөкләп, күтәреп ачу. *Газинур, чатырның ишеген кайтарып керә-керә үк, күңелле тавыш белән кычкырды.* Г. Әпсәләмов.

8. Көчен киметү, туктату. *Немецлар атакасын әз генә булса да кайтару белән, актык төркемнәр дә [елганы] кичә башладылар.* Ш. Маннур.

9. Катлап үрү, катлап чыгу (чабатаны). *Чабатаны кайтаруын гына кайтар, үрүен кирәк кем дә үрер.* Мәкаль.

10. Кисү коралларының йөзен үтмәс хәлгә китерү. *Атна буена чәч арасына утырган ком-тузаннар пәкесенең йөзен шунда ук кайтаралар, күрәсең. [Чәч алучы] минут саен --- янап азаплана.* М. Гафури.

11. *рәв. мәгъ.* **кайтарып.** Яңадан, кабаттан. *Дворникның бу көтелмәгән сүзен Габделбасыйр авыз әченнән генә кайтарып әйтте.* Ф. Әмирхан. *Садыйк карт гаҗәпләнгән тавыш белән кайтарып сорады: „Нәрсә дисең?“* Ш. Камал.

Кайтарып калдыру — нәрсәгә дә булса сылтап, шуңа гына бәйләп калдыру. *Ләкин бөтен нәрсәне басымга кайтарып калдыру да ярамый.* М. Җәлил.

КАЙТМА *с.* Яңадан кабатлана торган. *Кайтма тиф.*

Кайтма реакция *хим.* — бер үк вакытта капмакаршы юнәлештә бара торган реакция.

КАЙТУ *ф.* **1.** Чыгып киткән, башланган урынга кире килү. *Каюм өйгә кайтып кергәндә, кояш яңа гына иңгән иде.* Ш. Камал. *Ферма артындагы таулар өстеннән көчле яңгыраш әйләнеп кайтты.* Г. Әпсәләмов. | Шул юнәлештә хәрәкәт итү. *Кызарып беткән шат балалар аякларын тигез басып, җыр белән урам буйлап кайттылар.* М. Мәһдиев.

2. Билгеле бер урынга товар, әйберләр һ. б. нәрсәләр килү. *Авылга --- һәртөрле машиналар һаман саен күбрәк кайта башлады.* Г. Галиев. *Кибеткә күн итекләр кайткан икән.* Г. Ахунов.

3. Тукталып торган нәрсәгә яңадан тотыну, кабат башлау. *Шул вакытта ук, әгәр гомерем булса, вакыт җиткерә алсам, бу әсәргә яңадан бер кайтырмын дип үз күңелемдә кистереп куйдым.* Г. Ибраһимов.

4. Электә булган хәлгә, торышка килү. [*Хәмит:*] — *Тормышка яңадан кайта аламмы дигән сорау минем күңелемдә утлы төен булып төйнәлгән иде.* Р. Ишморат. — *Кешеләр арасында бераз нормаль хәлгә кайткан кебек булдым.* Ә. Еники.

5. Баш тарту, тану (фикердән, сүздән). — *Юк, Газинур, син фикереңнән кайтма,* — [*диде Гөлләр*]. Г. Әпсәләмов.

6. Кимү (су, эссе һ. б.). — *Су бераз кайткач, төнлә белән барып алырбыз,* — *диде Шәрифҗан.* И. Гази. *Төш ауган, һава бераз тынычланган, көндезге кызу да кайткан.* Каз. утл. || *күч.* Егәрлеге, көче кимү, начарлану. *Соңгы елларда күзе кайта башлаганмы,* [*Байтирәктә*] *төпләнеп каласы килепме,* [*Шәмсетдин*] *ешрак күренгәли башлады.* Г. Бәширов.

Кайтып калу — кемгә яки нәрсәгә дә булса бәйләнгән булу. *Төп гаеп цех начальнигы иптәш Закировка кайтып кала.* Р. Ишморат.

КАЙТЫМ: кайтым юнәлеше *лингв.* — фигыльләрдә эш яки хәлнең субъектка кайтуын белдерә торган форма (мәсәлән, бизәнү, юыну).

КАЙТЫШ I *и. сөйл.* Чыгып киткән, башланган урынга кире килү, кайту күренеше. *Шигырьнең --- яңгырап кайтышы Габделбасыйрның үзенә әллә ничек моңлы --- тоелды.* Ф. Әмирхан.

КАЙТЫШ II *с. сөйл.* Күләме, әһәмиятлелеге, буйсыны һ. б. ш. сыйфатлары ягыннан кечерәк, кимрәк, түбәнрәк, тәбәнәгрәк (кемнән яки нәрсәдән). *Әптелбәр буе белән үзеннән аз гына кайтыш Габдуллаһы кулыннан тотып тартты.* Ә Фәйзи. || *хәб. функ.* [*Мифтах, Гали байларга*] *карата Сәхап картлар да кайтышрак иде.* С. Рафиков.

КАЙТЫШЛЫЙ *рәв.* Кайтып килгәндә, кайту ягында, кайткан уңайга. *Эштән кайтышлый Мохтар Саматовларга керде.* Ш. Камал.

КАЙЧАГЫНДА *рәв. к.* кайчакта. *Укыймын кайчагында Дәрдмәндне, Алып ташлый күңелдән барча дәртне.* М. Гафури. *Кайчагында бабай без аңламаган кызык кына сүзләр әйтеп куя иде.* Г. Гали.

КАЙЧАК *рәв. к.* кайчакта. *Д кайчак, төннәрдә, каты яңгыр шаулап уза.* А. Шамов.

КАЙЧАКТА *рәв.* Ара-тирә, вакыт-вакыт, кайбер вакытта. *Кайчакта син, Рәхим, бигрәк кызык сүзләр сөйлисең.* Р. Ишморат.

КАЙЧАН *а.* **1.** Вакытны билгеләү, ачыклау өчен сораганда кулланыла. — *Кайчан туй ясыйбыз соң, Гөлнар җаныйм?* Ә. Айдар. *Поезд кайчан килә икән?* А. Әхмәт.

2. *рәв. мәгъ.* Кайчакта, кайвакыт, вакыт-вакыт. *Кайчан шулай ашкыну һәм дулкынлану белән үткән көннән соң --- җыйнак бүлмәдә утны кабызмыйча тик кенә ял итеп утыргалыйм мин.* Ә. Еники. || Ике җөмләне яки җөмләнең ике кисәген бер-берсенә мәгънә ягыннан каршы куйганда һәрберсенең алдыннан кабатланып кулланыла. *Кайчан йомшак кичке җилләр исә, кайчан саз тарталар, көйлиләр.* Ф. Бурнаш.

3. *рәв. мәгъ.* Нинди вакытта, кайсы вакытта. — *Кайчан гына карама,* [*сестра*] *шунда иде.* А. Шамов. [*Сорау алучы Фәхринең*] *тимерчелеккә кайчан, кем белән китүләренә тукталды.* Г. Ибраһимов. || *сөйл.* Күптән, әллә кайчан. *Сездә дә гаеп, трактор соң Кайчан килде безнең кырларга.* М. Җәлил.

4. *мөн. сүз.* Баш җөмләдәге *шунда* сүзе белән мөнәсәбәткә кереп иярчен вакыт җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Җир өстендә кайчан алтын бетәр, шунда чыгар хаклык.* М. Гафури.

5. *Менә* кисәкчәсе белән килеп, эш-хәлгә мөнәсәбәтле вакытны абстракт билгеләү өчен кулланыла. *Менә кайчан пароход күрә икән Хәлим?* И. Гази.

Кайчан да булса — берәр вакыт, берәр кайчан. *Барыбер, кайчан да булса бер бармый хәл юк.* Ф. Әмирхан.

КАЙЧАНГЫ *а.* Кайсы вакытта, күптәнгеме булуын ачыклау өчен сораганда кулланыла. *Кайчангы хәл? Кайчангы вакыйга?*

КАЙЧАНДЫР *а.* Бервакыт. *Кайчандыр бу тауларда горур атлап Пугачев йөргән.* А. Әхмәт. *Кайчандыр ул егет карт белән балык промыслоларында эшләгән.* Ш. Камал.

КАЙЧЫ *и.* **1.** Баш һәм имән бармак өчен балдак сыман тоткалы кара-каршы ике пычактан торган, уртадан тоташтырылган кисү коралы (гадәттә, материя, калай, кәгазь һ. б. өчен). *Сарык кырку кайчысы. Калай кайчысы.* □ *Бүлмәдәге тынлыкны бары тик ямаулык кискәндә кайчының чыкылдавы гына боза иде.* М. Хәсәнов.

2. Түбәнең югарыгы очлары почмак ясап беркетелгән, түбәнге очлары бина, йорт һ. б. ш. стенасына утыртып куелган ике агачтан гыйбарәт терәге. *Лапас торыгына яңа кайчы утыртырга кирәк.* Ф. Хөсни.

Кайчы койрык *зоол.* — дымлырак урыннарда була торган, гәүдәсенең арткы өлеше ике япьле бөҗәк.

КАЙШАЛУ *ф. диал.* **1.** Гәүдә белән арткарак бөгелү, артка каерылу. [*Кәрим*] *кинәт артка кайшалды, ачкыч тоткан кулын гайрәт белән югары күтәрде.* Г. Ахунов.

2. *к.* каймыгу. *Аягы сынмаган, тубык турысыннан кайшалган гына.* М. Хәсәнов.

КАК [как] I *и.* Җиләк-җимешне изеп, юка гына җәеп кояшта киптереп ясалган әчкелтем чәй ашамлыгы. *Җиләк кагы. Алма кагы. Миләш кагы.* □ *Авылның барлык каралты түбәләре --- кояшка авышрак итеп фанер такталар белән куелган карлыган каклары белән капланган була.* Г. Галиев. *Нарат җиләге кагының шифасы тиде: картыбызга хәл керде.* Э. Касыймов. || *диал. к.* повидло. *Эш беткәч Рәйханә аларны тәмле как сумсасы һәм вареньелы чәй белән сыйлады.* А. Расих.

Как кою — как ясау. *Былтыр койган алма каклары син, — Аларга! — дип, һаман саклыйсыңмы?* А. Алиш.

КАК [как] II *с.* **1.** Коры, корыган; артык нык кипкән. *Как агач.*

2. Әйбер җәелмәгән, каты (мәс., идән һ. б.). *Махсус урын юклыктан, --- ятканда баш астына бүрекне салып, өскә җиләнне ябынып, как идәнгә ятарга туры килә иде.* М. Гафури.

3. *күч.* Бик ябык, коры сөяккә калган (кешеләр турында). *Аннан [карчык] тиресе сөякләренә ябышкан как бармаклары белән чыраның күмерен төшерде.* Ф. Кәрим.

◇ **Как сөяккә калу** — артык нык ябыгу. *Габдулла Тимериләргә кергәндә, Җаббар абзый сәкедә авырып ята, --- үзе как сөяккә калган иде.* Ә. Фәйзи.

КАКАДУ *и. зоол.* Тутый кошларның башында бүреге (2 мәгъ.) булган бер төре.

КАКАО *и.* **1.** Тропик агач, орлыгыннан шоколад ясала.

2. Шул үсемлек орлыкларыннан ясалган порошок һәм шуннан әзерләнгән әчемлек. — *Имәнбаев какао кайнаткан кәструлне өстәл өстенә китереп утыртты.* Ә. Айдар. *Гөлсем апа, термосыннан стаканга хуш исе аңкып торган --- какао салып, яралының күгәргән иреннәренә китерде.* Г. Гобәй.

КАКЛАГАН *с.* Ыслап киптерелгән (ит, балык, һ. б.). *Андрей, өстенә киеп, ашарына ипи белән каклаган дуңгыз ите алып каядыр чыгып китте.* А. Шамов.

КАКЛАНУ *ф.* **1.** Ыслану, кибү (ит, балык һ. б.).

2. Артык нык кибү (агач, такта һ. б.). *Идән, түшәм такталары тора-тора какланып беткән, кадак та керерлек түгел.* Ә. Еники.

КАКЛАУ *ф.* Ит, балык һ. б. ларны тозлап, ыслап киптерү. *Казларны көздән катырып, язга калганнарын тозлап каклыйлар.* А. Расих.

КАКМА[1] *и. сөйл. к.* шакылдавык. *Яңгыратып суга торган биек, текә какмалар — Гыйлаҗи кулыннан ясалып килә.* Г. Ибраһимов.

КАКОФЕ'МИЯ *и. лингв.* Әдәпсез сөйләү, тупас сөйләү.

КАКОФЕМИЗМ *и. лингв.* Әдәпсез сүзләр, тупас сүзләр.

КАКОФО'НИК *с. муз.* Аһәңсез, колакка ятышсыз, ямьсез.

КАКОФО'НИЯ *и. муз.* Аһәңсез, колакка ятышсыз авазлар җыелмасы. *[Остазы Хәбирга:] Теорияне өйрәнергә кирәк. Шунсыз зур әсәр язып булмый. Икенче тапкыр миңа мондый какофония китермә.* Ш. Хөсәенов.

КАКСУ *ф.* Тәмсезләну, бозылу. — *[Май] базда озак торган, каксыган, базарлыклы түгел!* Г. Бәширов.

КАКСЫТУ *ф.* Берәр нәрсәне озак тотып, тиешенчә сакламыйча тәмсезләтү. — *Дче балны, озак тотып, каксытып ташламыйк.* Ф. Хөсни.

КА'КТУС *и. бот.* Яфраксыз итләч сабактан гына торган чәнечкеле көньяк үсемлеге. *Кактус ише кояш яктысында гына үсә торган гөлләрне өйнең кояш төшә торган тәрәзәсе төбенә кую яхшы.* Азат хатын.

КАКТЫРЫП-СУКТЫРЫП *рәв. сөйл.* Читләтеп, төрттереп. *Кактырып-суктырып сөйләү.*

КАКТӨШ *и. к.* чәкчәк. *Берсе әйтә: „Киләсе кече атнага, Ногман хаҗиның кактөш мәҗлесе булачак, узган атнаны егерме сигез ат белән килен төшерделәр.* Г. Камал. *Әтисе Илдарга юлга дип пешерелгән кактөшне ашатты.* Г. Гобәй.

КАКЧА *с.* Чандыр, ябык. *Фәттери — кечерәк какча гәүдәле ир уртасы кеше.* Р. Төхфәтуллин. *Якуб абзыйның кара тутлы какча йөзе беренче карашка шактый кырыс күренә.* М. Хәсәнов.

КАКЧАЛАНУ *ф.* Чандырлану, арыклану. *[Зыя] кырык яшьтә, төсе уңган. Какчаланган. Чалланган.* Ә. Давыдов.

КАКЧЫЛ *с.* Ябыграк, чандыррак. *Гаяз --- какчыл гәүдәле, чандыр йөзле Гыймади абзыйга карап алды.* И. Гази.

КАКШАК *с. диал.* Какшаган. *Йортларның күбрәге какшак, басынкы, таушалган.* Ш. Камал.

КАКШАМАС *с.* Нык, җимерелмәс. *Какшамас дуслык. Какшамас нигез.* □ *Үзенең какшамас законча-лыклары буенча колхоз тормышы элекке ялчыны өлешле, мул тормышлы иткән.* М. Максуд.

КАКШАМАСЛЫК *с. к.* какшамас. *Күңелле күмәк эш аларга шактый зур шатлык һәм какшамаслык көч бирә иде.* Ш. Камал.

КАКШАТУ *ф.* **1.** Бушап, селкенеп тора торган хәлгә китерү. — *Әйдә [идәнеңне] какшатсыннар. Бер келәм сугарлык йоныңны эрләп бирделәр инде. Җимерелсә, келәм белән капларсың.* М. Фәйзи.

2. *күч.* Җимерү, таркату, бетерү, юкка чыгу хәленә китерү. *Дошманны шушында какшатырга кирәк. Монда безнең язмыш чишелә.* М. Галәү. *Какшатырга корыч сафыбызны Дошманга бирмә юл бер дә.* Ә. Исхак.

3. *күч.* Үзгәрү, кире якка үзгәртү (уй-фикер, дуслык, ышаныч һ. б.). *Ләкин ачуым-ачу, бу соңгы уемны ничек булса да какшатып, Мәрфуга ападан үч алмый калырга ярамый.* Ф. Әмирхан. *Нәгыйм --- [коммуна членнарының] бер-берләренә ышанычларын какшату ният белән --- коткы салырга маташты.* Ш. Камал.

4. *күч.* Арыту, йончыту. *Юл бик какшатты.*

КАКШАУ *ф.* **1.** Бушап, селкенеп тора торган хәлгә килү. *Идән паркетлары какшаган, танымаслык дәрәҗәдә каралган.* Каз. утл.

2. *күч.* Җимерелү, таркалу, бетү, юкка чыгу хәленә килү (хуҗалык, гаилә тормышы, тәртип һ. б. турында). *[Сабир] бик тиз авылга кайта һәм какшаган хуҗалыкны нигытып, үстереп җибәрә.* Г. Нигъмәти.

3. *күч.* Зәгыйфьләнү, начарлану (сәламәтлек турында). *Бигрәк тә япон сугышына барып кайтканнан соң, Галиулланың саулыгы какшады.* И. Гази. *Карт быел какшады.* Г. Галиев.

4. *күч.* Кимү, юкка чыга бару, кире якка үзгәрү (ышаныч, дуслык һ. б). *Сәлмән картның бу яңа хезмәтчегә булган ышанычы какшый башлады.* Ф. Хөсни. *—Халыкның ышанычын югалтып барасың, Борһан. Д халыкның ышанычы какшадымы, аннары бетте инде.* М. Хәсәнов.

КАКЫ *и. бот.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгыннан сабагы ашарга яраклы үлән үсемлек. *Балтырганнарга ияреп ачы какылар, кәҗә сакаллары күтәрелеп китә.* А. Гыйләҗев. — *Быел кузгалаклар шәп булдымы? Урман какысы белән балтырганнарны күп җыйдыгызмы?* З. Бәшири.

КАКЫЛДАУ *ф.* **1.** *к.* каңгылдау. *Каз какылдавын куймас, үрдәк бакылдавын куймас.* Мәкаль. *Казларга какылдамаска, үрдәкләргә бакылдамаска --- тыныч булырга әмер бирде [январь].* Г. Галиев.

2. *күч.* Кычкырып артык күп сөйләү.

КАКЫЛДАШУ *ф.* Каңгылдашу. [*Казларның*] *„Кыйгак!.. Кыйгак!.. дип какылдашкан, бер-берсе белән сөйләшкән тавышлары Ак күл буена ямь һәм җан биреп тора.* М. Гафури.

КАКЫЛЫК *и.* Какы күп үсә торган урын.

КАКЫРУ *ф.* Тавышланып тамакны какырыктан чистарту. [*Гата Хаҗи:*] — *Их, егетләр, егетләр!— диюдән башка сүз таба алмагач, юл өстенә какырды да, - - - өенә юнәлде.* К. Нәҗми.

КАКЫРЫК *и.* Сулыш юлларыннан һәм үпкәдән бүленеп чыга торган лайлалы эрен. *Какырыгында куренгән кан* [*Гайфуллинны*] *башта куркытты.* Г. Ибраһимов.

КАКЫРЫНУ *ф.* Һәрвакыт яки вакыт-вакыт какырып тору.

КАЛА *и. сөйл.* Шәһәр. *Бистәләрне узып, кырга чыктык, Калды, калды Казан каласы.* Ш. Маннур.

КАЛАЙ *и.* **1.** Юка табаклы тимер. *Көнозын кояш астында көеп яткан түбә калае күңелле шыбырдый иде.* Г. Әпсәләмов. *Хәлим шалаш түрендә ниндидер язулы икенче бер ак калай күрде.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Шундый тимердән эшләнгән. *Кичен Габдулла аскы өйгә төштә һәм калай самовар янында „Дбүгалисина“ны укыды.* Ә. Фәйзи.

2. Төрле ашамлыклар пешерү, кыздыру өчен читләрен бөгеп шундый юка тимердән ясалган сай савыт. *Печенье калайларын тозга манчылган газета кәгазе белән чистарталар.* Азат хатын.

◇ **Калай күзле** — нурсыз, төссез күзле. *Ашарга сорап маташа торган калай күзле карчык чынлап та ярлы карчык икән.* Г. Толымбай. **Калай этәч** — 1) бәйләнергә, сугышырга яратучан кеше.— *Ах, әле син шулаймыни? Күп күргән мин синең кебек калай этәчләрне!* Ялкын; 2) мактанчык, шапырынучы кеше. — *Калай этәч син, белдеңме! Нәчәллек булып йөрергә яратасың.* А. Расих. **Калай этәчләнү** — 1) кызулану, хулиганлану; 2) мактану, шапырыну.— *Вакыйфның калай этәчләнеп йөрүе бер бүген генәме әллә? — диде әкмәл.* А. Гыйләҗев.

КАЛАЙЛАНДЫРУ *ф.* Нурсызландыру, тондыру (күзне). *Ул, күзен калайландырып, тагын шул элекке сүзен сөйли башлады.* Г. Толымбай.

КАЛАЙЛАНУ *ф.* Тону, нурсызлану (күзләр турында). — [*Тана*] *барыбер мантымас, дидем, күзләре калайланган иде.* С. Рафиков. *Әче балдан* [*мулланың*] *кысык күзләре калайлана, теле бәйләнә башлаган иде.* И. Гази.

КАЛАЙЛАУ *ф.* Нәрсәне дә булса калай белән каплау, калай белән тышлау.

КАЛАЙЛЫ *с.* Калай белән капланган, калай сугып эшләнгән. [*Зиннәт*] *калайлы яшел сандык өстендә торган графиннан күп итеп су эчте.* Г. Бәширов.

КАЛАЙЧЫ *и.* Калай эше белән шөгыльләнүче. *Кукмара ягы кешеләре — һөнәргә оста кешеләр, пыяла куючылар, итекчеләр, калайчылар җитәрлек монда.* Г. Ахунов.

КАЛАЙЧЫЛЫК *и.* Калайчы һөнәре, калайчы кәсебе.

КАЛАК *и. диал.* **1.** *к.* балкашык. *Исхак калак очына гына әләктереп бал капты.* А. Гыйләҗев.

2. Берәр нәрсәнең кин, яссы очы (мәс., ишкәкнең, балчык изгечнең һ. б.). *Көймәсе өчебезгә өчәү, ишкәкләре дә бар, сабы ак, калаклары күк.* Г. Гобәй. *Пропеллерның калаклары кыекланып ясалганга күрә, әйләнгән чакта ул·һаваны бораулап, көрәп артка ташлый.* С. Баттал. || Бер башы шулай көрәк сыман киңәйтелеп эшләнгән әйбер. *Ипи калагы. Сука калагы.*

3. Пароходта ишү тәгәрмәченең такталары.

4. *диал. к.* янавыч. *Мин дә - - - чалгымны янадым, калагымны оек кунычына тыктым да картның артыннан төштем.* Г. Ибраһимов.

5. Аяк киемен җиңелрәк кию өчен кулланыла торган, ике кырые бөгеп, очы ярымтүгәрәк формада эшләнгән җайланма. *Аяк киеменең арты туры, бөкләнми саклансын өчен махсус „калак“ белән кияләр.* Азат хатын.

Калак оны — *к.* көрәк оны. [*Хәлим:*] *Тегермәннәрегездә калак оны яшерәләр.* И. Гази. **Калак сөяге** *анат.*— арканың югары өлешендә өчпочмак формасындагы яссы сөяк.

КАЛАМБУР *и. әд.* Бер үк сүзнең төрле мәгънәләрен яки аваздаш сүзләрне очраштыру юлы белән комик эффект тудыра торган тел-сәнгать чарасы. *Яңгура үз каламбурына үзе канәгать булып көлеп җибәрде.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Шундый чарага нигезләнгән. *Каламбур рифма.*

КАЛАМБУРЛАУ *ф.* Каламбур белән сөйләү, әйтү. *Каламбурлап язган.*

КАЛАМБУРЧЫ *и.* Каламбур кулланырга яратучы.

КАЛАНЧА *и.* Тирә-юньне күзәтү өчен тар һәм биек итеп эшләнгән баскычлы корылма. *Каланчаның күзәтү мәйданчыгында ике кеше сыярлык итеп ясалган озынча скамья бар.* Г. Гобәй. *Кыңгыраулы биек каланчадан Карап тора Янгын сакчысы.* Ш. Мөдәррис.

КАЛАЧ *и.* Ак күмәч. *Әзләп кенә ашыйбыз дип ашый торгач, калач яртыга кала язды.* М. Гафури.

Калач алка — зур түгәрәк алка.

КАЛАЧЧЫ *и.* Калач пешерүче, калач пешерү остасы.

КАЛГАН-ПОСКАН *с. к.* калдык-постык. *Габдулла хан, үзенең тәхетен кайтарып алу өчен, калган-поскан гаскәрен җыеп моннан ярты көнлек юлда, Ташкүпердә тора.* Н. Исәнбәт.

КАЛГУ *ф.* Йоклап китү; йокыга ою, йокымсырау. *Шәйхи - - - утырган килеш калгып китүен сизми дә калды.* И. Туктар. || *күч.* Тынычлану, басылу, онытылу. *Калгыган уй-хыялларны уяту.*

КАЛДАУ *с.* Иген чәчелми калган, яткын (җир турында). *Кыз, чүп үләннәр баскан калдау җир буенча, тиз-тиз болынга төшеп китә.* С. Рафиков. || *и. мәгъ. Быел эш җиңел булмас, әллә кайчангы калдауларны күтәрәбез.* Г. Галиев.

Калдау үлән — кар астында кышлаган үткән елгы үлән.

КАЛДАУЛЫК *и.* Калдау урын. [*Сәхап Сәйфуллинның*] *- - - болынга башлаш калдаулыктагы өчпочмаклы җире — кимендә дүрт гектар.* С. Рафиков.

КАЛДЫК *и.* **1.** Эш процессында берәр нәрсәдән артып калган кисәк. *Материя калдыгы.* □ *Тау-тау итеп өеп куелган такта калдыклары күзгә күренеп юк була торды.* М. Хәсәнов. | *с. мәгъ. Калдык материя кисәгеннән тәмәке янчыгы тегеп бирү әллә нәрсә түгел инде.* Ш. Камал.

2. Җимерелүдән, һәлакәттән яки таркалудан һ. б. калган нәрсә, кисәк. *Юл буендагы машина калдыклары, унар, уникешәр йортлы кечерәк, күбесе жимерелеп беткән авыллар — барысы да кар астында калганнар.* Г. Әпсәләмов. [*Якуб:*] *Шул отрядларның калдыкларыннан яңа отряд оештырып җибәрсәк, бик зур таяныч булыр иде безгә.* И. Гази.

3. Эшкәрткәннән яки файдаланганнан соң калган ташландык, яраксыз нәрсә. *Нефть калдыклары. Кухня калдыклары.* □ *Өем-өем яткан консерв банкалары, аш калдыклары - - - бу юлларда - - - эшелоннар торганын белдерәләр.* Ш. Усманов.

4. *мат.* Бер санны икенче санга бүлгәндә бүленми калган өлеш. *Ун — икегә калдыксыз бүленә.*

5. *күч.* Искелектән, үткәндәгедән калган күренеш. [*Горький*] *фольклорны феодаль-крепостнойлык калдыкларына каршы көрәшкә көчле коралларның берсе итеп алды.* Г. Нигъмәти.

КАЛДЫК-ПОСТЫК *с.* Әз-мәз генә калган. *Малайлар күпер салган җиргә барып калдык-постык йомычкалар җыеп кайттылар.* Г. Гобәй. — *Инде* [*аларның*] *калдык-постык отрядларын бетерәсе калды.* Ш. Камал. || *и. мәгъ.* Ташландык, яраксыз нәрсәләр. *Юлга алып чыккан азыклардан Актырнакка да өлеш чыкты. Аңа да, бераз булса да, икмәк кисәкләре, салкын итнең калдык-постыклары эләкте.* М. Гафури.

КАЛДЫРУ *ф.* 1. Кая да булса киткәндә, барганда үзең белән алмау. *Без атны карт имән төбенә бәйләп калдырдык.* Ф. Хөсни. *Әйберләрне Габделкаюмга калдырып, дхмәтҗан белән Хаммат конторага кереп киттеләр.* М. Гали. || Нәрсәне дә булса билгеле урынга кую, урнаштыру һ. б.; кая да булса киткәндә берәрсенә тапшыру өчен бирү һ. б. [*Зөһрә Наилгә:*] *Хатыңны әнисенә биреп калдырдым.* Р. Ишморат. [*Доктор:*] *Хәле авыр булганга кертмәдек, менә бүген ул миңа записка калдырган.* Г. Ибраһимов.

2. Үзеннән соң берәр нәрсәнең барлыкка килүенә, чыгуына сәбәпче булу. *Акрын гына баткан кояшның күк йөзендә калдырган ялкынлы кызыллыгы каракучкыллана башлады.* Ф. Әмирхан. *Имәли шулай минем күңелемдә аңлашылмый торган ямьсез тойгы калдырып китте.* М. Әмир.

3. Берәр нәрсәне кем өчен дә булса саклау; бүлеп кую, аерып кую; яки нинди дә булса максат белән сайлап алып калу. *Нәселгә калдыру. Орлыкка калдыру.* □ *Менә бу кып-кызыл, эп-эре иң тәмле җиләкләрне әниемә дип калдырдым.* А. Әхмәт. || Саклап калу, тимәү; бөтенләй юкка чыгармау, бетермәү. [*Җәмиләнең*] *өйдә кич ашарга калдырган әрәк икмәге бар бит әле.* М. Гафури. [*Аучы*] *тик, ничектер, бер үрдәкне Атмый калдырган.* Ф. Кәрим.

4. Кемнең дә булса файдалануына, карамагына бирү, тапшыру. || Үзеннән соң нинди дә булса мираска, милеккә ия итү. *Драматург буларак, Г. Камал — татар әдәбияты дөньясы өчен бик бай һәм кыйммәтле мирас калдырган язучы.* М. Гали. *Минем атам мирас итеп Алтыннар калдырмаган.* Ә. Ерикәй.

5. Кемнең яки нәрсәнең дә булса торышын, аның нинди хәлдә, күренештә булуын үзгәртмәү; шул торышын, хәлен, күренешен саклау һ. б. *Иректә калдыру.* □ [*Кемдер*] *ишекне ачык калдырып, мич алдына таба уза башлады.* М. Әмир.

6. Нәрсәдән дә булса мәхрүм итү, алып китү яки бирмәү. *Сез нәрсә, колхозны счетоводсыз калдырмакчы буласызмыни инде?* А. Әхмәт.

7. Нинди дә булса максат белән тоткарлау; берәр нинди сәбәп белән җибәрми калу, үткәрмәү. *Дәреслеләрен кабатлатырга дип, сылтау табып,* [*Әхмалланы*] *укудан соң берничә мәртәбә уз янымда калдырдым.* А. Шамов. *Мирхәйдәр* [*Габдулланы*] *ай-ваена куймый чәй эчәргә кыстап калдырды.* Ә. Фәйзи. || Нинди дә булса урын, эш тәкъдим итеп алып калу; эштән чыгармау. *Деканат* [*Камаловны*] *аспирантлыкка калдырырга карар бирде.* М. Гали. *Мин, сезнең киңәшегезне тыңлап, Галинны вакытлыча үзенең урынында калдырырга күнгән идем.* Ш. Камал. || *сөйл.* (Класстан) күчермәү. *Капка аша гына торучы --- бер карчык --- былтыр оныгын классында калдырган өчен Гөлсем апага ачу тотып йөри иде.* Г. Гобәй.

8. Каян да булса яки берәр кеше яныннан чыгып китү. *Тын ярлар беренче Боз белән катканда, Партизан отряды Шәһәрне калдырды.* Ә. Исхак. || Ташлап китү, кайгыртучысыз, тәрбиячесез итү. [*Кабил әкълимәгә:*] *Калдырма син ялгыз мине.* Һ. Такташ.

9. Берәр урынга яки эшкә бармый калу. *Марат бүген дәрес калдырды.* || Берәр юнәлешне читләтеп китү, үтү. [*Илсөяр*] *як-ягына каранды да, сукмакны сулда калдырып, тау битендәге зәңгәр мәчетле авылга юнәлде.* Г. Гобәй. || Укыганда, язганда, сөйләгәндә һ. б. вакытта берәр нәрсәне төшерү, әйтми үтү. *Вахит беренче елларда хатларның һичбер сүзен калдырмый, әнәсеннән-әҗебенә чаклы укып чыгып --- әсәрләнә торган* [*иде*]. М. Гафури. *Нәфисә* [*Галиябану ролен*] *кыш көне генә уйнавын юри әйтми калдырды.* Г. Бәширов. || Берәр нәрсә эшләргә комачаулау, мөмкинлек бирмәү турында. [*Фәхрия:*] *Гәрәй абзый, зинһар дип әйтәм --- эшемне калдырасыз.* Ш. Камал.

10. Берәр эшнең вакытын алмаштыру, икенче вакытка күчерү. *Докторлар нервларың да бик нык какшаган дип укуны бер елга калдырып торырга киңәш бирәләр.* Һ. Такташ.

11. Кемнән яки нәрсәдән узып китү, алга чыгу. *Алмачуар „әһ“ дип бер суырып ала да, күк бияне аршын ярым чамасы калдырып, мәйданга килеп тә керәбез.* Г. Ибраһимов.

12. Берәр нәрсә белән килешмәүне яки берәр нәрсә турында сөйләүдән туктауны таләп иткәндә кулланыла. — *Әй, калдыр әле син кызларны... хәбәрне тыңла.* Р. Ишморат. [*Нургали Мирвәлигә:*] *Абый, әйдә бу мәсьәләне калдырыйк.* Т. Гыйззәт.

13. Нинди дә булса уенда отылырга мәҗбүр итү. *Шашка уенында җиңелмәү белән танылган Шәрәфи агайны бу көннәрдә Гарифның берничә мәртәбә „нужникта“ калдыруы ипташлар арасында --- әһәмиятле вакыйга булып китте.* Ш. Камал. || Берәр төрле уңайсыз хәлдә калырга мәҗбүр итү. *Хатыны ташлап китте --- һәм Сафаны --- бөтен дөньяга көлкегә калдырды.* А. Шамов.

14. Юклык формасында килеп, барысын да, бөтенесен дә эшләү, карау, әйтү һ. б. аңлата. *Яз, Нияз, күңелеңдә ни бар, Берсен дә калдырмый яз!* Ә. Исхак. [*Биби:*] *Һәр көн орыш та талаш, аз гына бернәрсә булыр хәл юк, хәзер тиргәргә тотына, һичбер әйтмәгән сүз калдырмый.* Г. Камал.

КАЛДЫРЧА *и. диал. к.* калтырча.

КАЛЁВКА *и.* Такта һәм планкаларның читләрен фигуралап ышкылау өчен кулланыла торган ышкы.

КАЛЕЙДОСКОП *и.* Эченә бер-берсенә почмак ясап берничә озынча көзге һәм төрле төстәге пыяла ватыклары яки кәгазь кисәкләре һ. б. урнаштырылган, бер башы тоник пыяла белән капланган катыргы трубкадан гыйбарәт оптик прибор. Пыяла яки кәгазь кисәкләренең көзгеләрдә чагылышыннан төрле төстәге симметрик фигуралар барлыкка килә (балалар уенчыгы буларак киң таралган).

КАЛЕНДАРЬ *и.* Төрле белешмәләр белән бергә эзлекле тәртиптә елның барлык көннәр исемлеген биргән таблица яки кенәгә. *Стенага элгән календарьның ертылмаган соңгы ун көне.* М. Җәлил. *Варис алдына җәеп салган календареның бер битенә нәрсәдер язып куйды.* М. Хәсәнов.

КАЛИБР *и. махс.* 1. Ату коралы көпшәсенең диаметры, юанлыгы. *Мин үзем эре калибрлы туплар батареясында хезмәт итәм.* А. Расих.

2. *тех.* Масса күләмендә эшләп чыгарыла торган кайбер предметларның төгәл зурлыгы.

3. *күч. сөйл.* Нәрсәнең дә булса зурлыгы, формасы, күләме, төре. *Ишек буена өелгән төрле калибрдагы 6—7 баланы күргәч,* [*Зозуля*] *артына чүгеп куйды.* Г. Ахунов. *Мәгъри карчык Г. Камалның башка әсәрләрендәге төрле калибрдан булган шундый тип карчыкларның художество ягыннан яхшы эшләнгәннәреннән берсе булып тора.* М. Гали.

КАЛИ'БРЛАУ *ф.* Нәрсәнең дә булса калибрын тикшерү, үлчәү, сортларга, бер иш нәрсәләргә аеру. *Ишниязга миналарның стабилизаторлары өчен канатлар калибрлау эшен бирерләр.* Г. Әпсәләмов.

КА'ЛИЙ *и. хим.* Көмеш сыман ак төстәге йомшак металл.

КАЛКАВЫЧ *и.* Кармак җебенә яки ятьмәгә беркетелгән, су өстендә батмыйча тора торган бөке, кайры кисәге һ. б. *Дулкын кузгалды, калкавычлар бер күтәрелделәр, бер төштеләр.* А. Алиш. || *с. мәгъ.* Су өстендә батмыйча калкып тора торган. *Караңгы су өстендә анда-санда калкавыч маяклар гына төн пәрдәсе аша каяндыр килеп чыгалар да артта калып тагын караңгылык эчендә югалалар.* С. Сабиров.

КАЛКАН *и.* Борынгы гаскәриләрнең кылыч, сөнге кебек салкын кораллардан саклану өчен тактадан яки металлдан махсус эшләнгән кул сугышы коралы. *Җик калканы белән үзен саклый-саклый каршы тора.* М. Җәлил. || *күч.* Саклагыч, сакчы. *Авыр язмыш [Хәернисаны] яшь килен ягыннан әрем-тел Сабирага каршы калкан булып барырга эчтән — күңелдән омтылдырды.* Г. Ибраһимов. *Төн капласа җирне, ир — ал таң! Афәт килсә илгә, ир — калкан!* М. Хөсәен.

Калкан чәчәк *бот.* — зонт формасындагы чәчәк.

КАЛКАНСЫМАН: калкансыман биз *анат.* — кеше һәм хайваннар организмында матдәләр алмашынуда катнаша торган эчке секреция бизе. *Рәхим ясаган беренче тәҗрибә калкансыман бизләрнең эшчәнлеге белән карындагы микрофлора арасында бәйләнеш бар икәнлеген әйтте.* А. Расих.

КАЛКУ I *ф.* 1. Күтәрелү, тору, аякка басу (кешеләр турында). *Кемнәрдер урыннарыннан калыкты, куллар күтәрелде.* Г. Бәширов.

2. Сыеклык эченнән өскә күтәрелеп чыгу. *Бу юлы су астыннан малай калыкты, ә немец калыкмады.* Г. Гобәй. || Каты әйбер эченнән яки астыннан бәреп чыгу (су, пар, тир һ. б.). *Иңбашын кисә капчык бавы, Тирле аркалардан калка тир.* Ф. Кәрим. *Боз өстенә су калыккан икән.* И. Гази. || Күпереп, кабарып чыгу; барлыкка килү (мәсәлән, тәндә берәр нәрсә). *Тамак авырта, муенга бизләр калыккан.* Ш. Камал.

3. Үсү, зураеп китү, күтәрелү (игеннәр, балалар һ. б.). *Яшел келәм булып калка чирәм, Язгы һава әйбәт булганга.* З. Мансур.

4. Күтәрелү, чыгу (күк җисемнәре турында). *Ай калкып, болыт арасында югалды.* Г. Ибраһимов. *Күктә калка Чулпан йолдызы.* Ә. Ерикәй.

5. *күч.* Күптән булган вакыйгалар, булган хәлләр һ. б. искә төшү. *Күп гасырлар инде әлек моннан Булган истәлекләр калыкты.* Ә. Исхак.

Калкып чыгу — 1) *к.* калку 2, 3, 4. *Дулкын астыннан башта Бикмүш бабай, аннары Илсөяр калкып чыкты.* Г. Гобәй; 2) барлыкка килү. *Управляющийның йөзенә аклы-кызыллы таплар калкып чыкты.* И. Туктар; 3) күптән онытылган нәрсәнең яңадан килеп чыгуы, көн тәртибенә куелу, күтәрелү. *Моңарчы күтәрелеп тә томалана килгән мәсьәләләр яңарып калкып чыктылар.* М. Әмир.

КАЛКУ II *с.* 1. Күтәрелеп торган, калкып торган. *Калку кырларда хәтфәдәй яшел уҗымнар күренде.* Г. Гобәй. || *и. мәгъ. к.* калкулык. *Урманнан чыгып сөргән җир арасыннан бер калкуга күтәрелдек.* Ф. Кәрим.

2. Чыгынкы, кабарынкы. *Зәйнәпбану кышын-җәен өзлексез тирли торган калку кызыл маңгаен кытыршы куллары белән сыпырды.* Г. Бәширов. *Шундый калку борынлы иде Мөхәммәтгариф.* Ә. Фәйзи.

3. Озын, зур, биек. *Беренән-бере кечкенә бу ятимнәр - - - үзләреннән аз гына калкурак булган апаларына күзләрен тутырып карыйлар.* Г. Гобәй. *Уналты да бәлки тулмагандыр. Тик ул бары калку гәүдәле.* Ш. Маннур.

4. *Күч.* Ачык, сәнгатьле, аерыбрак, ачыграк итеп, ассызымлап (бирү, гәүдәләндерү турында). *Бигрәк тә мәсхәрәләнгән, гаепсезгә хур ителгән кыз белән - - - ата трагедиясе калку итеп күрсәтелә.* М. Җәлил.

КАЛКУЛАНУ *ф. кайт. юн.* 1. Күтәрелеп тору, калку булып тору яки күренү.

2. Үсеп китү, буйга озынаю. [*Баланың*] *күзләрендә тереклек нуры артты һәм гәүдәсе дә калкулана бара.* С. Рафиков.

КАЛКУЛЫ *с.* 1. Калкулар булган, таулы, күтәренке (рельеф).

2. Кабарынкы, чыгынкы. *Карчыга борынлы, яңак сөякләре калкулы йөзле, кырма сакаллы Садыйк шулай күп сөйләнә иде.* А. Алиш.

КАЛКУЛЫК *и.* Тирә-юнь белән чагыштырганда биегрәк булып, күтәрелеп торган урын. *Нуруллин калкулык итәгенә таба киткән иптәшен күрергә теләде, ләкин аны таба алмады.* А. Шамов. || *геогр.* Диңгез өсте тигезлегеннән 200 *м* чамасы биек булган урын. *Идел буе калкулыгы. Урта Рус калкулыгы.*

КАЛКЫМ *и.* Калкып торган урын. [*Аның*] *йөзе ябык, яңак калкымнары чыгып тора.* Г. Әпсәләмов.

КАЛКЫНУ *ф.* 1. Кузгалу, яткан яки утырган урыннан аз гына күтәрелү. *Дүрт яралы, мендәрдән калкыналар да, күзләрен түгәрәкләндереп тыңлап тораларлар.* И. Гази. *Учак янындагылар шундук калкындылар.* Э. Касыймов. || *күч.* Тик, гамьсез яшәү хәленнән чыгу, хәрәкәткә килү. *Калкын!.. Җыел!.. Бөек эш галәмә! Дөнья безне тагын бер күрсен!..* М. Җәлил.

2. *күч.* Үсү, зураю. — *Малайлар да җирдән калкыналар: олысы ярый хәзер тырмага.* Ш. Маннур.

3. *сөйл.* Кемнең дә булса күз алдында, тирәсендә булу, буталып йөрү. [*Сәкинә:*] — *Монда җизниләргә кунаклар килә, калкынып йөрмә!* Ә. Камал. *Сафин - - - Хәйрия тирәсендә бик ныклы калкына иде.* Ш. Камал.

КАЛКЫТУ *ф.* Югарырак, өскәрәк күтәрү, калку итү. *Салих, уянган кешедәй, бердән башын калкытты.* Г. Минский. *Гайния - - - ак алъяпкыч белән билне кысып, күкрәкне калкытып бәйләде.* Г. Ибраһимов.

КАЛЛИГРАФ *и.* Каллиграфия остасы; матур язу остасы. *Карикатурачылыктан кала, Г. Камал үз заманында танылган каллиграф та.* М. Гали.

КАЛЛИГРАФИК *с.* Каллиграфиягә мөнәсәбәтле. *Каллиграфик язу.*

КАЛЛИГРА'ФИЯ *и.* Матур итеп язу сәнгате, матур почерк. *Каллиграфия остасы.*

КАЛЛИГРАФЧЫЛЫК *и.* Матур итеп язу эше, һөнәре. [*Г. Камалның*] *актерлык, карикатурачылык һәм каллиграфчылык кебек хезмәтләрен дә онытырга ярамый.* М. Гали.

КАЛМЫК *и.* Калмык Автономияле республикасында яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. || *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Калмык теле.*

КА'ЛОМЕЛЬ *и. мед.* Хлорлы терекөмеш; медицинада эчне йомшарту һәм дезинфекцияләү чарасы буларак кулланыла.

КАЛОРИ'МЕТР *и. физ.* Җылылык микъдарын үлчәү приборы.

КАЛОРИМЕ'ТРИЯ *и. физ.* Физиканың төрле җисемнәрнең җылылык микъдарын үлчәү белән шөгыльләнә торган бүлеге.

КАЛО'РИЯ *и.* 1. *физ.* Җылылык микъдарын үлчәү берәмлеге.

2. Тере организмның бер грамм азыктан эшләп чыгара торган, калорияләр белән исәпләнгән энергия микъдары. *Туклануның гомуми калориясен азайту*

өчен икмәк, ярма - - - һәм татлы азыкларның күләмен киметергә - - - кирәк. Азат хатын.

Кечкенә калория — бер грамм чиста суны бер градуска җылыту өчен кирәк булган җылылык микъдары. **Зур калория** — мең кечкенә калория.

КАЛО'РИЯЛЕ *с.* Зур калория бирә торган, җылылык калориясе зур булган. *Калорияле күмер.*

Калорияле азык — туклыклы, организмга зур энергия бирә торган азык; җимле азык.

КАЛО'РИЯЛЕЛЕК *и.* Зур калориягә ия булу, калорияле булу. *Азыкның калориялелеге.*

КАЛӨШ *и. к.* галош.

КАЛПАК *и.* 1. Очлаеп киткән, түгәрәк һ. б. ш. формалы материя яки йон баш киеме. *Повар калпагы. Клоун калпагы.* □ *Хәлим пиджагын салып чөйгә элде дә ак халат, ак калпак киде.* Г. Гобәй.

2. *махс.* Төрле формадагы капкач, япкыч. *Самовар калпагы.* □ *Йомры кечкенә калпагын менә-менә атып җибәрергә теләгәндәй ыргып кайнаган радиаторга Мөнәвир салкын су салды.* С. Рафиков.

КАЛТА *и. иск.* Күн акча янчыгы. *Су буенда, бит юганда, Калтам калган онытылып.* Җыр.

КАЛТАЮ *ф. к.* калҗаю. *Ялкын белән артык кызып китеп [башняның] кайбер такталары да калтайды.* Г. Галиев.

КАЛТЫЙ-КОЛТЫЙ *рәв.* Тигезсез юлда як-якка янтаеп, аугалап. *Бушап калган грузовик, калтый-колтый сикергәлән, ары китеп бара иде.* Г. Гобәй.

КАЛТЫРАВЫК *с.* 1. Калтырый торган. *Калтыравык кул.*

2. Өзек-өзек чыккан, калтырап торган (тавыш). *Өстәл янына утырган кеше аркасына мехлы пальто салган һәм үзе туңа торган кыяфәттә калтыравык тавыш белән ашыгып-ашыгып сөйли.* Ш. Камал.

3. *и. диал. к.* койкә. [*Миңлениса:*] *Койка куябыз, койка, килен, шул калтыравыкны үлеп яратам инде.* С. Рафиков.

КАЛТЫРАВЫКЛЫ *с.* Калтырап торган. *Күчәрбай елау катыш калтыравыклы тавыш белән үзенең гаепсез икәнлеген аңлатырга теләде.* М. Әмир. *Шәмнең калтыравыклы уты безнең йокы бүлмәсен аз гына яктырта иде.* Г. Рәхим. || *рәв. мәгъ.* Калтырап, тигезсез. *Әтинең ияге селкенә, еларга торган кеше кебек, сүзләре калтыравыклы чыга иде.* М. Гафури.

КАЛТЫРАНУ *ф.* 1. Дер-дер килеп селкенү (туңудан, куркудан яки җилдән). *Нургали бизгәк тоткандай калтырана башлады.* Ә. Еники. *Рәшә уйный нурда калтыранып, Арыш кырда серкә очыра.* Ш. Мөдәррис.

2. Өзек-өзек калтырап чыгу (тавыш турында). *Минем тавыш калтыранды, үземә ят булып тоелды.* Ә. Айдар.

КАЛТЫРАНУЛЫ *с.* Калтыранып торган, калтыравыклы. *Ләкин берничә секунд үтмәде, өзелеп, бөтерелеп чыккан калтыранулы курай авазы мине бөтенләй билән алды.* А. Шамов.

КАЛТЫРАТУ *ф.* 1. Калтырану хәленә китерү. *Көрәкләр авырайганнан-авырая, вибраторлар бөтен буыннарны калтыратып сызландыралар.* А. Гыйләҗев. *Күз алларым караңгыланып, бөтен тәнемне бизгәк калтырата башлады.* Т. Гыйззәт.

2. *з-сыз.* Салкыннан, куркудан һ. б. калтырау барлыкка килү турында. *Кышның январь вакыты булганга күрә, көн һаман салкын булып, чыгу белән туңдыра, калтырата башлый.* М. Гафури.

3. *күч.* Куркыту, куркуга төшерү. *Кызның сүзе егетне калтыратты.* Ә. Баянов.

КАЛТЫРАУ *ф.* 1. Тәндә еш һәм вак-вак хәрәкәтләр ясалу, дер-дер килү (салкыннан, куркудан, берәр төрле авырудан). *Харрас бер агарына, бер кызара, куллары калтырый.* Ә. Айдар. *Кул-аякларым дердер калтырый, йөрәгем леп-леп тибә.* М. Әмир. || Еш-еш, тигезсез тибү (йөрәк турында). *Тик сине күрергә Мин киләм бу чакта, йөрәгем калтырый Бизгәктәй шул чакта.* М. Җәлил. | *и. мәгъ. Вахитны калтырау алды.* М. Гафури. *Бөтен тәнендә [Нәҗиянең]вак калтырау йөри.* Ә. Еники. || Тирбәлеп, дерелдәп тору (җансыз әйберләр турында). *Гайшә кинәт тынды, шуның артыннан ук кечек өйнең тәрәзәсендәге бетәргә хәзерләнеп калтырап торган шәм дә сүнде.* Г. Ибраһимов. *Соргылт йортлар да, ерактагы завод морҗалары да ничектер калтыраган кебек.* К. Нәҗми.

2. Тигезсез, өзек-өзек булып чыгу, яңгырау (тавышлар турында). *Гафиятулла бабайның тавышы калтырый һәм ике күзеннән мөлдерәп яшь ага иде.* Г. Әпсәләмов. *Килененең зур ачылган, очкынланган күзе, гарьләнеп калтыраган тавышы карчыкны айныта төште.* Г. Бәширов.

3. *рәв. мәгъ. күч.* Кемне яки нәрсәне артык кадерләп, җан атып кайгыртып яшәү турында. *Менә безнең сөеп, калтырап асраган улыбыз... — дип сүзгә керешкән идем, ул: — Куй - - - анда сөйләрбез - - - диде.* Ш. Камал.

◇ **Калтырап тору** — 1) саклап тоту, артык саранлык күрсәтү, бер бөртеген дә әрәм итмәү турында. *Бер тиен өчен калтырап тора ул;* 2) курку, хәвефләнеп яшәү турында.

КАЛТЫРАУЛЫ *с. к.* калтыравыклы. *Калтыраулы аваз.*

КАЛТЫРЧА *и.* 1. Киндер сугу өчен шүрегә җеп чорный торган корал. [*Нәгыймә*] *сәке астыннан калтырчасын алып, шүре ясады.* М. Гали. *Калтырчалар, шыгыр-шыгыр җырлап, Җеп чорныйлар курай шүрегә.* Ш. Маннур.

2. *күч.* Озак файдаланудан искергән, җимерелү хәленә килгән төрле машиналарга карата көлеп әйтелә. *Бөтенесе җыелып беткәч, Миңнәхмәтнең „калтырчасыннан“ [тракторыннан] көлә-көлә, бер көйрәтеләр.* Сов. әд.

КАЛУ *ф.* 1. Билгеле бер урында торуны, булуны дәвам итү, аннан китмәү. *Җиңги белән абый өйдә калдылар.* Ә. Айдар. *„Сугышлы“ халкының бер өлеше совхозда кала, бер өлеше икенче районга күчеп утыра.* Г. Әпсәләмов. || Нинди дә булса урында үзеңнең булуыңны, торуыңны берәр нинди максат белән дәвам итү. *Дивизия командирының турыдан-туры кушуы буенча, дошман тылында разведкада калдык.* А. Шамов. || Алынмау сәбәпле берәр җирдә булуны дәвам итү. *Хат өстәл өстендә кала.* Г. Камал. *Арыш яшелрәк урылганга төшми, көлтәдә кала.* М. Гали. || *сөйл.* Берәрсе янында булу, кем белән дә булса булу. *Рөстәм Мәрфуга белән кала.* Һ. Такташ.

2. Кемне дә булса алыштыру, кемнең дә булса урынын алу. *Атасы узган кышын чирләп үлгәч, Саимә өчен бердәнбер якын кеше булып Нәсимә калган иде.* К. Нәҗми.

3. Нинди дә булса хәлдә, торышта булуны дәвам итү. *Утырган килеш калу. Дус булып калу. Тәрәзә ачык калу.* || Үз фикерләрен, карашларын, принципларын һ. б. үзгәртмәү турында. *Ләкин ул һаман үз сүзендә калды.* Ф. Әмирхан. || Бер класстан икенче класска күчә алмау турында. *Классында калу.*

4. Нинди дә булса хәл, сыйфат үзгәрешсез саклану. *Каеннарның, беләм, кәүсәләре Кала һаман ап-ак көенчә.* З. Мансур. || Хәтердә, башта тору; хәтерләү, истә булу. [*Абый*] *минем күңелдә әллә ничек басынкы, авыр табигатьле бер кеше булып калган.* Г. Гали. *Хәтеремдә шулай калган: күпердән чыккач, уң якта - - - бер бина бар иде.* Г. Галиев. || Югалган, юкка чыккан нәрсәнең калдыгы, әзе сыйфатында булу. *Халык*

телендә аның әкият итеп сөйләрлек сүзләре генә калды. А. Шамов. *Хәзер комбинат эвакуацияләнгән, заводның буш корпуслары һәм күккә сузылган төтенсез трубалары гына калган.* Г. Әпсәләмов. || Кем дә булса үлгәч, яшәүне, торуны дәвам итү. *Үзем үлсәм, балаларым кала, Минем гомерем булып — Ватаным.* Ф. Кәрим. || Чыгымнардан, файдаланганнан соң да бетмәү. *Хәзер шүрлектә бер генә конфет калды.* Д. Аппакова. [*Әминә*] *сугыштан алдагы елларда калган, Шакирны каршылау өчен саклап тоткан „Магнолия“ исле маен сөртенде.* Г. Минский.

5. *з-сыз.* Нәрсә дә булса эшләргә генә кирәк булу, туры килү, тиеш булу турында. *Сугып амбарга салассы гына калды.* Ш. Камал. *Землянкаларның икесе казылып беткән, тик түбәләренә туфрак ташлыйсы гына калган.* Г. Әпсәләмов.

6. Нинди дә булса чик, момент килеп җиткәнче билгеле бер зурлыкны тәшкил итеп тору. — *Ямансазга моннан тугыз гына чакрым калды, — дип сөйләнә-сөйләнә атын борды* [*карт*]. К. Нәҗми. *Күп булса, ярты сәгать вакыт калды.* Ш. Усманов.

7. Бер-бер хәлгә төшү, бер-бер хәлдә булу. *Су астында калды тугайлар.* Г. Хуҗи. *Балалар белән урам уртасында калсаң, кая барыр идең.* М. Әмир. || Нинди дә булса киемне салганнан соң өлешчә яки бөтенләй киемсез булу турында. *Яланбаш калу. Яланаяк калу. Костюмнан калу.* □ *Гаяз күлмәген салып, майкадан калды.* М. Шәрифуллин. || Ятим, тол һ. б. хәленә төшү. *Гөлсем апа әти-әнисеннән бик яшьли калды.* Г. Гобәй.

8. Кемнең дә булса өлешенә тию, аның карамагына, милкенә күчү (йорт-җир, мирас, китап һ. б.). *Йорт балаларга калу.* □ *Габделкаюмның әбисе Бибигамбәр абыстай - - - карты Хөсәеннән калган кульязмалар укый.* М. Гали.

9. Берәр нәрсәдән мәхрүм булу; нәрсәне дә булса югалту. *Йортсыз калу. Эшсез калу.* □ [*Нуруллин*] *сул кулсыз калды.* А. Шамов. || Билгеле бер табигый сәләтне, халәтне югалту. *Баладан калу. Йокыдан калу. Ашаудан калу.* □ [*Давыт*] *телдән калды.* А. Гыйләҗев. || Нинди дә булса яман, куркыныч хәлдән котылу. [*Шәмсия:*] *Бичара егет, мине таптатмас өчен, машинасын баганага бәреп ваттырган. Шулай итеп үлемнән калдым.* Т. Гыйззәт.

10. Берәр нәрсә янышнан үтеп китү турында. *Андасанда ялтыр көзге төсле җемелдәшеп калды буалар.* Ш. Мөдәррис.

11. *сөйл.* Карта яки башка шундый уенда отылып, уен атамасы исемен алу. *Җүләр калу. Кәҗә калу.*

12. Башкаларга караганда әкренрәк бару яки юлда тоткарлану сәбәпле артта булу. *Иң артка калып, арык кына, ямьсез генә бер туры ат килде.* М. Гали. *— Әйдә калмагыз,— диде Хәлим һәм бер-ике атлауга тагы нәрсәгәдер килеп бәрелде.* Г. Гобәй.

13. Башкаларга караганда әкренрәк эшләп, вакытында үти алмау, бетерә алмау, иң соңгы булу. *Башкалар күптән эшләрен тапшырдылар, ә мин калдым.* А. Гыйләҗев.

14. Әкрен үсеш нәтиҗәсендә тиешле дәрәҗәгә җитмәү, башкалар белән чагыштырганда түбәнрәк булу турында. [*Гариф:*] *имеш, мин тормыштан калып барам, оппортунист, янәсе.* Р. Ишморат.

15. *сөйл.* Берәр төрле транспортка утырып китәргә өлгерә алмау. *Поезддан калу. Самолеттан калу.*

16. *юкл. форм.* **калмау.** Янындагы юклык формасында килгән фигыль аңлаткан эшнең һичшиксез эшләнәчәген, үтәләчәген белдерә. [*Сафура:*] *Мин үз сүземне итми калмам.* А. Әхмәт. [*Галиябану:*] *Бүген инде* [*Хәлил*] *янына чыкмый калмыйм.* М. Фәйзи.

17. *юкл. форм.* **калмау.** Үзеннән алдагы исем аңлаткан предмет тулысынча тикшерелгән, үтәлгән һ. б. булуны белдерә. *Укымаган китап калмады. Бармаган җир калмады.* □ *Мин тикшердем күктә һәр йолдызны, Мин белмәгән йолдыз калмады.* Ә. Ерикәй.

18. Чыгыш килешендәге тәмамлыктан соң килеп, тиеш булган урынга бармауны белдерә. *Бары тик авыру яисә яшь баласын калдырырга кешесе булмаган хатыннар гына эштән кала иделәр.* Ш. Камал. *— Мин бит әле - - - өч көн дәрестән дә калдым.* Д. Аппакова.

19. Юнәлеш килешендәге исемнән соң килеп: 1) үз вакытында башкармау, нинди дә булса вакытка кичектерү турында. *Суга барсаң, иртәрәк бар. Соңга калсаң, комлана.* Җыр. [*Карлыгач:*] *Юк, язга калырга ярамый, көздән үк, бәйрәм үткәч үк!* Г. Бәширов; 2) берәр нәрсә белән генә чикләнү (ашау-эчүдә мохтаҗлык турында). *Бәрәңгегә калу. Ипи белән суга калу.*

20. -ырга -рга формасыннан соң: 1) берәр максат белән билгеле бер урында булуны дәвам итү. *Укырга калу. Эшләргә калу.* □ *Бәрән суырга калган иде бит ул.* Г. Гобәй; 2) уфтану, үкенү, ачыну мәгънәләрен аңлата. *Бары да ерак, бәхетле, матур төш кебек сагынып уйларга, сагынып еларга калды.* Г. Ибраһимов; 3) бары тик шулай гына эшләргә туры килү, башка чара булмау мәгънәсен аңлата. *Йөгерергә кала. Ашыгырга кала.* □ *— Безгә хәзер күбрәк хәйлә белән алдырырга кала, — диде Гарифуллә.* Г. Минский.

21. Йокы, эш, уен һ. б. ш. исемнәрдән соң килеп, шулар белдергән хәлнең булмавын, үтәлмәвен, башкарылмавын аңлата. *Йокы калганга күрә, без Харрас белән - - - көне буе йокладык.* Ә. Айдар. *Уйнасам, дәресем кала* [*диде бала*]. Г. Тукай.

22. Көлкегә, оятка, хурлыкка һ. б. ш. сүзләрдән соң: шул хәлгә төшү мәгънәсен аңлата. *Саттаров иптәшләре алдында оятка калмаска тырышса да, булдыра алмады.* А. Шамов. [*Гыйльми карчык:*] *Минем кызларым да, уларым да болай хурлыкка калып, акылдан язып ятканнары юк.* М. Гафури.

23. *ярд. ф. функ.* Хәл фигыль янында килеп: 1) эш-хәлнең тәмамланмавын, дәвам итүен белдерә. *Галимә җиңги белән длфия аларның артыннан хәерле юл теләп, кул болгап калдылар.* Г. Әпсәләмов; 2) мөмкинлек булу, шуннан файдаланырга тырышу, мөмкинлектән файдалану мәгънәсен аңлата. *Чана юлы өзелгәнче ташып калырга кирәк.* Г. Гобәй. *Тәнемдә көч, йөрәгемдә дәрт бар чакта эшләп каласым килә минем.* Р. Ишморат; 3) эш-хәлнең нәтиҗәсен белдерә. *Уң кашының бер чите, йөзен шадралаткан чәчәк авыруы чагында бераз чокырланып, сыекланып калган.* Г. Ибраһимов. *Бик озак елларга чаклы Көмешле күл тирәсе күңелсезләнеп калган.* Г. Галиев; 4) билгеле бер торышка, хәлгә күчүне белдерә. *Ул бераз сәерсенеп, бусага төбендә туктап калды.* Г. Бәширов. *Нәрсәдер буласын сизеп, класс тынып калды.* А. Әхмәт; 5) эш-хәлнең тиз арада, өлешчә генә булып үтүен белдерә. *Габдулла күз кырые белән генә Сәрвинең, сөлгене тотып, өйгә кереп китүен күреп калды.* Ә. Фәйзи.

24. *ярд. ф. функ.* *-сы* кушымчалы сыйфат фигыль белән килеп: 1) алда эшләнәсе эш, үтәләсе нәрсә булуны аңлата. *Басмалар инде алынган, юеш арканнарның элмәкләрен генә чуен тумбалардан ычкындырасы калган иде.* К. Нәҗми. *Инде калдык-постык отрядларны бетерәсе калды.* Ш. Камал; 2) үтәлмәгән, башкарылмаган эш өчен үкенүне белдерә. *Күз керфекләрем талганчы Карыйсым калган икән.* Җыр.

25. *бәйл. функ.* **кала.** 1) урынны яки вакытны белдергән саннлы тезмәләр янында тулы күләмгә җитми

калган микъдарны күрсәтү өчен кулланыла: калдырып, калдырганда. *Сәгать алтыга нәкъ ун минут кала клубка, ачык партия җыелышына киттеләр.* А. Расих. [*Илсөяр*] *чатырга йөз-йөз илле адым кала: — Җомагыл абый, пароход! - - - дип кычкырып бардыбарды да, кире борылып, будкага таба чапты.* Г. Гобәй; 2) соң, тыш, башка. *Г. Камалның әдәбият өлкәсендә драматургиядән кала иң күп эшләгән жанры — поэзия.* М. Гали.

КАЛФАК *и. этн.* Сәйләп яки эндә белән чигелеп, бәрхеттән тегелгән, маңгай турысына киелә торган хатын-кыз баш киеме. *Гайнинең өстендә тар гына йон күлмәк, башында энҗеле калфак.* Г. Камал. *Күпертмә чәчләренә энҗе калфаклар кадаган* [*кызлар*] *хуш исле кофе тараттылар.* А. Гыйләҗев.

КАЛФАКЧЫ *и.* Калфак чигү остасы. *Калфакчы Сара кызының болай кинәт күтәрелеп китүе күпләрнең көнчелеген уятты.* Г. Ибраһимов.

КАЛФАКЛАП *рәв.* Яулыкны алгы яктан калфакка охшатып, маңгайга төшереберәк арттан бәйләү турында.

КАЛШАЮ *ф. к.* калжаю. [*Тегермән*] *канатларының җил-яңгырда калшаеп, ватылып баруы да ачык шәйләнде.* А. Гыйләҗев.

КАЛЫМ *и. этн.* Кызның ата-аналарына кияү ягыннан акчалата яки әйберләтә бирелә торган йолым (кайбер көнчыгыш халыкларда ыруглык чорыннан калган йола). *Мин калымга бирмәм алтыннар.* Ә. Ерикәй.

КАЛЫМЛЫК *и.* Калым түләү өчен билгеләнгән акча, әйбер, мал-туар. [*Этиләр*] *калымлык өчен йөз терлек, биш йөз сум акча, ике сандык асыл зат алып куйганнар.* Г. Ибраһимов.

КАЛЫН *с.* **1.** Аркылы кисеме зур булган; киресе: юка. [*Әнисе Габдуллага*] *зур гына телем икмәк кисеп, аның өстенә калын гына итеп бал ягып бирде.* Ә. Фәйзи. *Менә инде Нуруллин, урыннан торып, калын кара материядән тегелгән халаты белән уралып, палата буенча әкрен генә йөри.* А. Шамов. || Берничә кат әйбердән торган. *Калын бишмәт.* || *рәв. мәгъ. Кат-кат. Бары да калын киенгән.* Ф. Бурнаш.

2. *к.* юан. *Менә калын тирәк турысыннан яр ишелде.* К. Нәҗми. *Кара, калын чәч толымнары ялтырап, авыр чулпылар моңлы гына чыңлап үттеләр.* И. Туктар.

3. Куе (чәч, каш, урман һ. б. турында). *Авыл, иркен кыр, калын урманнарга кушылып, тавышсынсыз гына ял итә.* Ф. Кәрим. *Калын кара мыеклар аңа мәһабәт төс биреп торалар.* Р. Ишморат.

4. Тулы, юан гәүдәле (кеше). *Рәхим калынрак егеткә бәйләнергә тотына.* Ф. Әмирхан. *Берсе зур, калын гәүдәле, икенчесе аның янында бала кебек кенә.* Ә. Айдар. || Итләч (тәннең, битнең аерым урыннары турында). *Менә бер төркем халык арасында калын гына иренле тимер юл эшчесе шома иттереп сөйли иде.* Ш. Камал.

5. Гүләп чыккан, түбән, тупас (тавыш турында). *Төзелеш башлыгының ышанычлы калын тавышы кешеләрне үзенә тартты.* С. Рафиков. *Машина калын тавыш белән үкерә башлады, барабан тешләре - - - зырылдап әйләнергә тотындылар.* Г. Бәширов.

◇**Калын тиреле** — бер нәрсәгә дә исе китми торган, гамьсез (кеше турында).

КАЛЫНАЙТУ *ф.* **1.** Калын итү. *Байлар кесәсен калынайтыр өчен эшлисең дә эшлисең.* Ш. Камал.

2. Юан итеп күрсәтү. *Бөрелеп тегелгән күлмәк калынайта.*

КАЛЫНАЮ *ф.* **1.** Калынлык арту. *Боз калынаю. Кар катламы калынаю.*

2. Тазару, юанаю (кеше турында). [*Низаминың*] *сөйләме, аяк атлавы да шул! Тик бераз калыная гына төшкән.* Г. Ибраһимов. [*Хәйретдиннең*] *мускуллары да калынайган, беләкләре дә юанайган.* М. Гали.

3. Калынга әйләнү; тупаслану (тавыш турында). [*Салаватның*] *сүзләре кинәт салмакланган, тавышы калынайган сыман булып китте.* А. Шамов.

КАЛЫНЛЫК *и.* **1.** Предметның аркылы кисеменең зурлыгы. *Тузан ярты аршын калынлыгында өелеп ята.* Ш. Усманов.

2. Калын булу сыйфаты.

КАЛЫНЛЫ-НЕЧКӘЛЕ *с.* Калын һәм нечкәдән торган. *Сугышчылар калынлы-нечкәле тавышлар белән, шулай да шактый ук батыр тонда - - - җавап бирделәр.* Г. Бәширов.

КАЛЫНУ *з-сыз, к.* калу (1 мәгъ.). *Невод һәр көн ике мәртәбә салына, җил булып, диңгез дулкынланыбрак китсә, бер* [*белән*] *генә дә калына.* Ш. Камал.

КАЛЫНЧА *с.* Калын гына, калынга тартымлы. *Ул - - - үзенең калынча тавышы белән йомшак кына сөйләп китте.* Г. Бәширов.

КАЛЫП *и.* **1.** Аяк киемнәре теккәндә, эшләгәндә кулланыла торган, аяк табанына охшатып агачтан ясалган форма. *Югары шүрлектә әтисе* [*Габдулла өчен*] *калыпка тартып куйган читек башы тора.* Ә. Фәйзи. || Эшләпә һ. б. ш. кебек әйберләргә билгеле бер рәвеш бирү өчен кулланыла торган форма. || Рәвеш, форма. *Шунда бер якка иске йозак, - - - калыбы җимерелгән кәләпүшләр, бишмәтләр, - - - калфаклар берәм-берәм урнаша башлыйлар.* Г. Ибраһимов.

2. *махс.* Корыч һ. б. металларны эретеп коюда кулланыла торган форма. *Кайсылары суга, кайсылары калын тимерләрне бөгәләр, Кайберләре эрегән чуеннарны Алып, калыпларга түгәләр.* М. Гафури. || Кирпеч сугу эшендә кулланыла торган форма.

3. *әд.* Матур әдәбиятта чынбарлыкны чагылдыру чаралары һәм алымнары җыелмасы; форма. *Темалары ягыннан да, материалны әдәби калыпка салып бирә белүләре белән дә өч ипташнең өчесе өч төрле.* Ф. Хөсни. *Менә моңысын үзем язып алдым — шигъри калыпка салдым.* Ж. Тәрҗеманов.

4. *күч.* Әзер үрнәк, штамп, шаблон.

Калыпка салыну — билгеле бер җайга, көйгә салыну (тормыш, эш һ. б.). *Безнең тормыш бер калыпка салынып, ипле генә, җай гына бара башлады.* Э. Касыймов. [**Бер**] **калыпта сугылу, булу** — охшаш булу, бертөсле булу. [*Хәнәфи:*] *Барыбыз да бертөсле, бер калыпта сугылган.* А. Гыйләҗев.

КАЛЫПЛАНУ *ф.* Билгеле бер формага, рәвешкә керү. [*Рамазан Шәрифнең*] *хәтта фәсе дә рәтләп калыпланмаган һәм дә чит буйлары каешланып беткән.* Ш. Камал. *Шигырьләрдә - - - фикри яклары дөрес калыпланып җитә алмаган урыннар бар.* Г. Ибраһимов. *Почерк дигән нәрсә гажәп бит ул. Бер калыпланганнан соң ул аз үзгәрә.* А. Расих.

КАЛЫПЛАУ *ф.* Калыпка тарту, калыпка кидерү; калыпка салу. *Кәләпүшне калыплый торгач, Сәмигулла абзый* [*кинәт*] *туктады.* Г. Газиз.

КАЛЫПЛАШУ *ф.* Нинди дә булса формада ныгып калу, урнашу. *Сүзләр гомумән иҗтимагый хезмәт процессында, кешеләрнең производство практикасында туалар һәм шул процесста алар теге я бу төп мәгънәдә һәм формада калыплашалар.* Ш. Рамазанов.

КАЛЫШУ *ф.* **1.** Барганда, хәрәкәт иткәндә кемнән дә булса артта калу, аның адымына өлгермәү. [*Артыкбикә*] *тугай тавына күтәрелә башлагач җитез яшь малайлардан калышмады.* М. Әмир. || Эштә, ярышта башкалардан артка калу, башкалар кебек эшли алмау. *Бу Галимә менә дигән егетләрдән калышмый.* М. Гафури.

2. *күч.* Үзенең эше, сыйфаты һ. б. ягыннан башкалардан түбән булу. *Гомумән алганда, „Уйнаш" драматик эшләнеше ягыннан „Бәхетсез егет"нең соңгы басмасыннан калыша төшә.* М. Гали.

КАЛЬВИЛЬ *и.* Алмагачның көньяк сорты; алмасы алсу-сары төстә.

КАЛЬГА *и. иск. к.* крепость. *Бир син миңа --- Дошманнарның бивк кальгаларын Тар-мар итеп ваткан кулыңны.* М. Гафури. [*Хан:*] *Кальга дивар ларының нигезенә Тугзак батырларының гәүдәләрен салыгыз.* М. Җәлил.

КА'ЛЬКА *и. махс.* **1.** Сызым яки рәсемнәрнең күчермәсен алу өчен махсус эшкәртелгән үтә күренмәле кәгазь. *Стеналарда калька кәгазьләренә төшерелгән геологик карталар.* Ә. Айдар. *Чертежлар Роза тарафыннан ватман, калька кәгазьләренә эшләнгән проектлар һәм планнар иде.* Г. Кутуй.

2. *лингв.* Икенче бер телдән төгәл тәрҗемә итеп алынган сүз (мәсәлән, корнеплод — тамыразык, живой уголок — җанлы почмак). *Калька баштарак сәеррәк яңгырый, шуңа күрә аны кайберәүләрнең үз итеп бетермәве дә мөмкин.* С. Фәйзуллин.

КА'ЛЬКАЛАШТЫРУ *ф.* **1.** Калька ярдәмендә төгәл күчермә алу. *Сызымны калькалаштыру.*

2. *лингв.* Икенче бер телдән төгәл тәрҗемә итеп сүз ясау. *Рус сүзләрен калькалаштырып алу.*

КАЛЬКО'ГРАФ *и. махс.* Калькография белгече.

КАЛЬКО'ГРАФИЯ *и. махс.* Бакырны чокып рәсемнәр, бизәкләр төшерү. *Калькография мастерское.*

КАЛЬКУЛЯ'ТОР *и. махс.* Калькуляция ясаучы. *Кадрлар бүлеге начальнигы мине столовойга калькулятор итеп билгели.* А. Расих.

КАЛЬКУЛЯ'ТОРЛЫК *и. махс.* Калькулятор хезмәте.

КАЛЬКУЛЯ'ЦИЯ *и. махс.* Товарның, продуктның үзкыйммәтен һәм сату бәясен исәпләп чыгару. *Калькуляция ясау.*

КАЛЬКУЛЯ'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Калькуляция ясау.

КАЛЬМАР *и. зоол.* Башаяклы моллюсклар.

КАЛЬСОН *и.* Озын балаклы ирләр ыштаны (эчке кием).

КА'ЛЬЦЕКС *и. мед.* Гриппка каршы кулланыла торган дару.

КА'ЛЬЦИЙ *и. хим.* Химик элемент — көмеш сыман ак төстәге металл. *Бункерларда химик реакцияләр бара... Кальций исе аңкып тора.* М. Хәсәнов.

КАЛЬЦИТ *и. махс.* Известь, мрамор һ. б. ларның состав өлеше, известь шпаты. [*Иванов кесәсеннән икенче таш алып:*] — *монысы кальцит,* — [*диде*]. А. Әхмәт.

КАЛЬЯН *и.* Көнчыгышта тәмәке тарту приборы (анда төтен су аша чистарып уза).

КАЛӘМ *и.* **1.** Кара яки тушь белән язу өчен нечкә, ярык очлы, ике кырые улак сыман бөгеп эшләнгән корыч пластинка. *Вакыт-вакыт каләмнең ныклыгына эчен пошыра.* Ш. Камал. || Металл каләмнәр барлыкка килгәнгә кадәр язу өчен кулланылган, очланып ясалган эре каурый. — *Мә, читкә алып китеп пычрат алайса,* — *дип, Габденнасыйр* [*Габделкаюмга*] *кәгазь белән кара һәм каурый каләм бирә.* М. Гали.

2. *диал.* Карандаш. *Газинур дәфтәре белән каләмен противогазына тыкты да тиз генә урынынан торды һәм өстен-башын рәткә китерә башлады.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Язучылык сәнгате, хезмәте, символы буларак кулланыла. *Каләме шома егетнең, Зөлфә язып алган истәлекләрне ул үзе үк менә дигән иттереп төзәтеп чыккалар иде.* Э. Касыймов. *Хәлил — каләм белән гомер итүче егет.* Г. Колэхметов.

4. Гомумән, язучылык эше; фәнни хезмәт һ. б. ш. белән шөгыльләнүче кеше. *Каюм Насыйри тарафыннан башланган --- гыйльми, фәнни мәгълүматны, тәрҗемә эшләрен хисапсыз күп каләмнәр* [*дәвам итте*]. Г. Ибраһимов.

◇ **Каләм йөгертү** — 1) оста, тиз язу. [*Уразгөл*] *Идриснең кытыршы битле кәгазь өстенә каләм йөгертүенә --- карап сокланып торды.* Ә. Айдар; 2) гомумән берәр нәрсә язу. **Каләм каш** — сызылып киткән нечкә кара каш (кызларда). *Кайсы илнең кызы син? Алтын ука чәчең бар, Кыйгач каләм кашың бар.* М. Җәлил. **Каләм остасы** — сүз сәнгатеннән оста файдаланучы язучы. **Каләм сабы** — ручка. *Тагын бер кырыйда — кара көмештән коелган мәһабәт бер лачын сыны, чын сәдәптән эшләнгән лира һәм каләм сабы.* Г. Бәширов. **Каләм сынау** — язып карау (башлап язучылар турында). [*Г. Камал*] *өйрәнчек язучы сыйфатында, төрле жанрларда язып, үзенең каләмен сынап карый.* М. Гали. **Каләм тибрәтү** — 1) берәр нәрсә язу. *Әллә ничек база алмадым мин каләм тибрәтергә, Бәлки бүген көчем җитәр Телем белән әйтергә.* М. Җәлил; 2) язучылык белән шөгыльләнү. **Каләм хакы (каләм балы)** *иск.* — гонорар. — *Каләм тибрәтү --- сездән, каләм хакы миннән!* [*диде Кәбир әфәнде*]. Ә. Фәйзи. [*Мине газетада мактасаң*], *ди, аның өчен юл башына утыз тиенгә чаклы каләм балы түләр идем, ди.* Г. Ибраһимов. **Каләм өйрәнү** *иск.* — укырга-язарга өйрәнү. **Каләме өметле (күренү)** — башлап язучының таланты, сәләте булу турында. — *Болай синең каләмең өметле генә күренә,— диде Тукай* [*Хариска*]. М. Гали.

КАЛӘМДӘШ *и.* Иҗат эшендәге иптәш, дус, хезмәттәш, коллега. *Республикадагы каләмдәшләр, Баш шәһәргә саумы килдегез?* С. Хәким.

КАЛӘМЛЕК *и.* Кошларда контур каурыйларының мамыксыз урыны.

КАЛҖА *и.* **1.** Туралган ит кисәге. [*Баһави*] *тәмләп-тәмләп симез ит калҗаларын ашарга тотынды.* А. Расих.

2. *күч.* Төшемле урын, файда китерә торган эш. *Поезд Германия белән Франция арасында җәнҗаллы калҗа булган Эльзас-Лотарингия өлкәсенә таба йөгерә.* Г. Гали. *Колхоз кассасына илле мең сумга якын саф табыш керә. Ярыйсы калҗа!* Соц. Тат.

КАЛҖАЛАП *рәв.* Калҗаларга аерып, калҗаларга бүлеп, калҗа-калҗа итеп. *Табынга зур агач табак белән токмачлы аш, аның артыннан зур коштабак белән калҗалап туралган --- ит --- килә иде.* С. Рафиков.

КАЛҖАЛЫ *с.* **1.** Калҗалап туралган. *Калҗалы ит.*

2. *күч.* Төшемле, файда китерә торган. *Калҗалы эш.*

КАЛҖАЮ *ф.* Берәр нинди сәбәп белән тигезсез хәлгә килү, кәкрәю, бөгелү, чыгып тору (бүрәнә, такта һ. б.). *Су кырыенда, --- бүрәнәләре калҗаеп беткән һәм шул калҗайган бүрәнәләрне берничә җирдән терәтеп, кызыл балчык белән сыланган --- кечкенә генә бер өй тора.* М. Гали. || Кәкрәю, буынтыкланып калкып чыгу. *(Шәвәли карт) --- күзеннән бәреп чыккан яшь бөртеген кара тырнаклы калҗайган бармаклары белән яңагына сылап куйды.* Г. Ахунов.

КАМА [кама] *и. зоол.* Куе коңгырт төстәге кыйммәтле мехлы имезүче ерткыч су хайваны. *Сусарлар, аслар, кондызлар һәм камалар да җылы һәм матур мех бирәләр.* Зоология. || Шул хайванның тиресе. *Өстә спай кыска бишмәт, итәгенә, якаларына кама тоткан.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Шул хайванның тиресеннән тегелгән, эшләнгән. *Кама бүрек. Кама яка.*

КАМАКЫШ *и. диал. к.* аңкау.

КАМАЛАУ I *ф.* Кама тоту, кама мехы тегү.

КАМАЛАУ II *ф. диал. к.* камау. *Колхозчылар фронтовикны камалап өлгергәннәр.* Ә. Ерикәй. *Урамга чыккач, алты атлы казачий Мохтарны алдан-арттан камалап алып киттеләр.* Ш. Камал.

КАМАЛУ *ф.* Тирә-яктан камап алыну, камалышта калу. *Әмтә тентү башланган чакта өч катлы таш мәдрәсә тышкы яктан атлы казачий гаскәр белән камалып алынган иде инде.* Г. Ибраһимов. || *и. мәгъ. к.* камалыш. *Ничә айлардан бирле дошман камалуында ачлык азабы кичерә торган Ленин шәһәренә кадәр [икмәкнең] барып җитүен [Нәфисә] үз күзе белән күрәсе килә иде.* Г. Бәширов.

КАМАЛЫ *с.* Кама тоткан, кама белән чытләнгән (бүрек, тун һ. б.). *Аннары камалы тунлы, --- таза гына бер егет --- килеп чыкты да беркемгә бер сүз эндәшмичә китеп барды.* М. Гали. *[Саматның] башында кыңгыр киелгән камалы бүрек.* М. Фәйзи.

КАМАЛЫШ *и.* Кемнең яки нәрсәнең дошманнар тарафыннан чолганыштагы хәле. *Камалыштан чыгу.* □ *Революция бишеге — Ленинградның камалышта калуы бөтен совет халкын тирән хафага төшерде.* Г. Гобәй.

КАМАРИНСКИЙ *и.* Рус халык биюе көе һәм шул көйгә бию. *Кайсыберләре, ду күчереп, „Камаринский"-га басалар.* Ш. Камал. *[Шамил] мәханик рәвештә радионы бора. Ә анда камаринский музыкасы яңгырый.* Х. Вахит.

КАМАУ *ф.* **1.** Кемне яки нәрсәне дә булса уратып, әйләндереп алу; һәр яктан биләү. *Теге кешеләр Сәмигуллин өстәлен камап алдылар.* Ш. Камал. *Төрле яктан безне камыйлар.* И. Гази.

2. Чыгарга, чигенергә мөмкинлек калдырмый уратып алу, божрага алу. *Күңелле генә утырганда, бинаны полиция камады.* А. Расих. | *и. мәгъ. Иртәгесен 10 сентябрьдә Казан шәһәрен һәрьяклап камау һәм штурмлау башланды.* С. Сабиров.

3. *диал.* Кадерләү. | *и. мәгъ.* Кадер-хөрмәт. *Кияүгә торса да камау, утырса да камау.* Мәкаль.

КАМАУЛЫ *с.* Камап алынган, камалышта калган.

Камаулы рифма — шигырь строфасындагы беренче һәм соңгы юлларның рифмалашуы. *Ф. Кәрим аралаш рифмаларны куллану белән бергә, --- камаулы рифмаларны да еш кына куллана.* М. Максуд.

КАМАШУ *ф.* **1.** Ачы нәрсә ашаганнан соң тешкә тию, теш чагылу. *[Балаларның алма ашый-ашый] тешләре камашып беткән.* Д. Аппакова.

2. (Күзләр) чагылу (көчле яктылыктан, ачык төсле буяулардан һ. б.). *Дәрвиш белән егетнең бераз вакыт күзләре камашып тора.* Ш. Камал.

3. Ою яки артык арудан аякларның буйсынмавы, тигез, төз басмавы, йөрү тигезлеген югалту. *Әллә мин бераз исергән, әллә аяклар камашкан, әллә нинди, дулкындагы көймә өстендә барган шикелле, стеналар, идәннәр тирбәнә.* Г. Камал.

КА'МБАЛА *и. зоол.* Күзләре гәүдәсенең бер ягына гына урнашкан яссы диңгез балыгы.

КА'МБУЗ *и. махс.* **1.** Корабльдәге кухня. *Камбузга чәй алырга барышлый, Зәйтүнә дә кызыксынып туктаган иде.* С. Сабиров.

2. Казан куелган чуен яки тимер мич (корабльдә).

КАМВОЛЬ *и. махс.* Шома, юка тукымалар эшләү өчен китә торган тарап эшкәртелгән йон. || *с. мәгъ.* Шул йоннан эшләнгән. *Камволь тукыма.*

КАМЕ'ЛИЯ *и. бот.* Хуш исле ак яки кызыл төстәге эре чәчәк ата торган мәңге яшел көньяк үсемлеге һәм аның чәчәге.

КА'МЕРА I *и.* **1.** Төрмәдә тоткыннар өчен кысан бүлмә. *Тимер челтәрле тәрәзәдән камерага көн яктысы саркып керә иде.* Г. Әпсәләмов.

2. *махс.* Берәр прибор, машина, корылма эчендәге ябык пространство. *Менә проект, серле камера, Эчендә газ саркып югала, „В" билгесе янына клапан куйсаң, Газ куерып мичкә юл ала.* Ф. Кәрим. || Фотоаппаратның пластинка яки пленка куела торган эчке өлеше.

3. Һава тутырыла торган эчке резин тышча (шинда һәм тупта). *Кояш чыгып кыздыра башлагач, тәгәрмәчләр эчендәге һава жылынып киңәючән була. Шул чакта инде камералар тыгызланып тулалар.* С. Баттал.

КА'МЕРА II *с.* Музыкант-солистлар яки берничә катнашучыдан торган ансамбль башкаруы өчен билгеләнгән. *Шәһәр сәхнәләрендә симфоник концертлар, камера музыкасы һәм җыр авторлары концертлары булды.* Каз. утл.

КАМЕРАДАШ *и.* Камерада (1 мәгъ.) бергә утыручы. *Ике камерадаш --- кәбестә шулпасы ашадылар.* Г. Минский.

КАМЕРА'ЛЬ *с. махс.* Лабораториядә, кабинетта эшкәртелә торган (экспедиция материаллары).

КАМЕРГЕ'Р *и.* Монархик дәүләтләрдә: сарайда хезмәт итүченең камер-юнкердан югары дәрәҗә исеме. || Шул дәрәҗәгә ия кеше.

КАМЕРДИ'НЕР *и.* Буржуаз-дворян һәм дворяннар көнкүрешендә: йорт эшләрен яки хуҗаларның шәхси йомышларын һ. б. башкаручы ир хезмәтче.

КАМЕРИ'СТКА *и.* Дворяннар һәм сарай көнкүрешендә: хуҗа хатыны бүлмәсендә хезмәт итүче асрау.

КАМЕРТОН *и. муз.* Каты әйбергә сукканда билгеле бер югарылыкта тавыш чыгара торган ике япьле чәнечке сыман корыч инструмент: оркестрда музыка коралларын көйләгәндә, шулай ук хор белән җырлаганда кулланыла.

КА'МЕР-Ю'НКЕР *и.* Патша сараендагы һәм кайбер монархистик дәүләтләрдәге камергердан түбәнрәк дәрәҗә. || Шул дәрәҗәгә ия кеше.

КАМЗУ́Л *и.* Күлмәк өстеннән кия торган җиңсез һәм якасыз кыска өс киеме. *Биюче чикмәнен атып ташлап, кызыл күлмәк өстеннән камзул кигән итекле, матур, яшь бер егет булып кала.* М. Фәйзи.

КАМЗУЛЛЫК *с.* **1.** Камзул тегәргә билгеләнгән, камзулга җитәрлек. *[Хәмидә:] Күп дип әйтергә алар әллә нәрсә сорамыйлар: эче-тышы, әйләнәсе белән камзуллык чатма.* Г. Камал.

2. *и. мәгъ.* Камзул тегәргә яраклы материал. *[Галимә:] Шунда берочтан гына Садрига да камзуллык алырсың.* М. Фәйзи.

КАМИЛ *с.* **1.** Җитлеккән, өлгергән, балигъ булган. *[Фазыл] хәзер камил егет булып, ир булып үсеп җиткән инде.* Г. Ибраһимов.

2. Тулы. *Мәхәллә тормышының иң вак нәрсәләреннән башлап, иң эреләренә кадәр камил бер тәртипсезлек астында, бер анархия эчендә яшәү.* Ф. Әмирхан. *[Гайфуллә абзый] чыраена камил тынычлык вә ышанучанлык рәвеше бирепләр, --- яшь сабыйлар йокысы белән рәхәтләнеп йоклый булыр.* Ш. Камал. || *рәв. мәгъ. иск.* Җиренә җиткереп, тулысынча, тәмам. *Бу тиен акча Шәрифнең ихтыяҗына камил җиткән.* М. Гафури.

3. Иң әйбәт, бөтен җире килгән, бернинди кимчелексез. *[Кызның] буе-сыны, гәүдәсе дә, төсе-бите дә — бар җире дә камил.* Н. Фәттах.

КАМИЛЛЕК *и.* **1.** Камил, һәр яктан яхшы, бөтен җире килгән, кимчелексез булу. *Картның бик зур мәшәкать белән камиллеккә ирештергән зур, бай, матур бакчасы --- гына да, аны башка һәммә адәмнән әллә ничаклы аера вә югары куя.* Г. Ибраһимов.

2. Төгәллек, җиренә җиткереп эшләү. *Һөнәр осталары, улым, художник кебек алар: камиллекне яраталар.* Г. Әпсәләмов.

КАМИЛЛӘНҮ *ф. к.* камилләшү. *Күңелләрдә калды тик изгелек, Камилләнде җирнең һәр төше.* Каз. утл.

КАМИЛЛӘШТЕРҮ *ф.* 1. Камил хәлгә китерү, яхшырту. [*Балалар уенчык*] *пароходларны камилләштерүгә ярдәм иттеләр.* Г. Гобәй.

2. Төгәл, бөтен хәлгә китерү, тулыландыру. *Белемне камилләштерү.*

КАМИЛЛӘШҮ *ф.* Камил хәлгә килү, яхшыру. *Мәдинәнең нечкә борын, чем-кара күзләр, ул күзләрне уратып алган озын керфекләр, --- юка иреннәр — һәммәсе анасы йөзендәге сызыкларның тагын да камилләшә төшеп кабатланышы.* Ш. Хөсәенов.

КАМИ'Н *и.* Ягу урыны киң һәм ачык итеп салынган мич. *Мин янып торган камин алдында качалкада тирбәлеп утырам.* Каз. утл.

КАМКА I *и. зоол.* Өске каты канатлары кызыл, сары, ак төстә булып кара төрткеләр төшкән бөҗәк; *русчасы:* божья коровка.

КАМКА II *и. иск.* Кытай ефәге. *Кием кисәң камка ки, Эче тузмый, тышы уңмый.* Мәкаль.

КАМПА'НИЯ *и.* 1. *хәрби.* Билгеле бер урында барган кыска вакытлы сугыш. *Финляндия кампаниясенә катнашкан сугышчылар бу кышны яхшы беләләр.* Г. Әпсәләмов.

2. Берәр әһәмиятле ижтимагый-политик яки хуҗалык бурычын тормышка ашыру өчен билгеле бер вакыт эчендә үткәрелә торган эшләр. — *Мин сайлау кампаниясен уздырырга өяздән җибәрелгән агитатор-организатор булам!* Һ. Такташ. *Урып-җыю кампаниясен яхшы тәмам итүдә --- Булат иптәш арабызда Күпләрдән алда тора.* М. Җәлил.

КАМПА'НИЯЧЕЛ *с.* Кампания төсендә, эзлексез һәм системасыз, вакыт-вакыт кына үткәрелә торган. *Кампаниячел чаралар.* | *рәв. мәгъ. Күп кенә агитбригадаларның кампаниячел эшләүләрен икърар итәргә кирәк.* Соц. Тат.

КАМПА'НИЯЧЕЛЕК *и.* Эштә плансызлык, системасызлык. *Кызганычка каршы, бездә --- эштә декларативлыкка, кампаниячелеккә юл куйган --- работниклар да бар.* Тат. коммунисты.

КАМСА' *и. зоол.* Сельдь балыклары семьялыгына керә торган вак диңгез балыгы; хамса.

КАМУС I *и. иск. кит.* Сүзлек. *Ләкин урамга чыккан саен дүрт җилдле камусны култык астына кыстырып йөреп булмый.* Ф. Әмирхан.

КАМУС II *и. диал. этн.* Болан тиресеннән теккән аяк киеме. *Өстенә башлыклы болан туны, аягына камус кигән каюр килеп керде.* Каз. утл.

КАМУФЛЕТ *и. махс.* Снаряд яки минаның чокыр ясамыйча җир астында шартлавы.

КАМУФЛЯЖ *и. махс.* Орудиеләрне, корабльләрне, биналарны һ. б. маскировкалауның бер ысулы (төрле сызыклар, таплар һ. б. төшереп дошманнан яшерү).

КАМУФЛЯЖЛЫ *с.* Камуфляж ысулы белән маскировкаланган, төрле нәрсәләр төшерелгән. *Камуфляжлы плащ-палаткаларыннан корылган чуар чаршау ачылып китте.* Ш. Маннур.

КАМФАРА *и. мед.* 1. Көчле ис чыгара торган төссез кристаллик матдә (медицина һәм техникада кулланыла).

2. Шуннан ясалган сыек дару. [*Дгъләм*] *озак тормый янә һушыннан язды; аңа камфара уколы бирептордылар.* С. Рафиков.

Камфара мае — үсемлек маена кушылган камфара эремәсе, дару буларак кулланыла.

КАМЧАДАЛ *и.* Камчаткада яшн торган жирле халык вәкиле.

КАМЧАТ: камчат бүрек *этн.* — түбәсенә хәтфә, кырыена кондыз мехы тотылган бүрек (күбесенчә хатын-кыз кигән). *Вахит абзый белән камчат бүрек өстеннән калын шәл ябынып, кара чикмән бөркәнгән Бәдриҗамал җиңги шул чанага утырдылар.* М. Гали.

КАМЧАТЧЫ *и.* 1. Камчат бүрек тегүче, шундый бүрек тегү остасы. *Камчатчы Галиәкбәр малае дип тә йөртәләр иде үзен.* Ә. Фәйзи.

2. Камчат бүрекләр белән сәүдә итүче.

КАМЧЫ *и.* 1. Каеш яки баудан үреп, ишеп ясалган кыска саплы чыбыркы. *Кулымдагы сигездән үргән камчымны арбага, бау астына кыстырып, ат янына барам.* А. Гыйләҗев. || Җәзалау, суктыру өчен махсус кулланыла торган шундый каеш чыбыркы. *Бездә дә, ягъни яшьләргә дә, шул ук Усман урядникның камчысы эләкмәде түгел.* А. Шамов.

2. *әфв. сөйл.* Елан. *Елан димә — чага, камчы дисәң — кача.* Әйтем.

◇ **Камчы алу, камчы ашау** — кыйналу, камчы җәзасы алу. *Ә без, сиксәнешәрдән булмаса да, берәрикешәрдән һаман бик эче камчылар алгалаштырып тора идек.* Ш. Камал. *Ә Хөсәен мирза ачларга бирелгән онның һәр кадагы өчен миңа йөз камчы ашатырга вәгъдә итә.* Ф. Бурнаш.

КАМЧЫЛАУ *ф.* 1. Камчы белән сугып куу (атларны). *Полк командирының ординарецлары, әледән-әле колонна буеннан атларын камчылап, командирның приказын кычкырып үтәләр.* Г. Бәширов. || Суктыру, камчы белән җәзалау. [*Бикмүш бабай казакка:*] *Әллә шул баланы да камчылар идеңме?* Г. Гобәй.

2. *күч.* Тәнкыйтьләү. *Иванов та озын сөйләде. Аның сүзләре үзен камчылау, кылганга үкенү булып чыкты.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Елдырым уйнау, арышлар өлгергәндә ерактан яшен яшьнәү. *Аргы яктан болыт килә, Яшен яшьнәп, камчылап.* Г. Камал.

Камчылау уты — елдырым, ажаган. *Фронт сызыгы өстендә камчылау уты сыман ракеталар күтәрелә.* Г. Әпсәләмов.

КАМЫЛ *и. а.-х.* 1. Өлгергән ашлыкның көпшәсе, сабагы. *Бодай камылы. Арпа камылы.* □ *Арыш быел куе да, озын да, камылга да бик шәп.* М. Гали.

2. Игеннәрне урып жыйганнан соң тамыр өстендә калган сабак төбе. [*Комбайн*] *узган җирдә бодайлар юкка чыга бара, артында тәбәнәк камыл гына утырып кала иде.* Г. Гобәй.

КАМЫЛЛЫ *с.* Камыл белән капланган. [*Нуруллинның*] *ике иптәше, --- каты камыллы ызан буенча үрмәләп килә иде.* А. Шамов.

КАМЫР *и.* 1. Онны су, сөт һ. б. белән катнаштырып изүдән барлыкка килгән куе масса. [*Шәмсия*] *Алма бәлеше пешерсәк, камырга сөт кирәк.* Т. Гыйззәт.

2. *күч.* Йомшак, җебегән (кеше). *Әй, камыр, шуны да булдыра алмадың!* Сов. әд.

Камыр агачы, җимеше *бот.* — *к.* дүләнә. *Барсам, камыр җимеше ашарга барам.* А. Гыйләҗев. **Камыр ашы** — камырдан пешерелгән ашамлык. *Мөнәвәрә --- чәй янына --- кәрәзле баллар, камыр ашлары куйды.* А. Расих. **Камыр башы** — икенче вакыт камыр ачыту өчен махсус калдырылган яки суга чүпрә салып, он туглап кына ясалган ачы камыр. **Камыр кую** — (ачыту, кабарту) өчен сөткә яки суга чүпрә яки камыр башы салып он белән туглап кую. [*Бибиҗамал апа*] *талкыш кәләвә пешерде, пәрәмәчлек камыр куйды.* Ш. Хөсәенов.

◇ **Камыр батыр** — батырлыгы житмәгән кешегә карата мыскыллап әйтелә (эшият героена охшатып кулланыла). *Шуннан хатын сузып яткырды Бу котырган камыр батырны.* М. Җәлил. **Камыр булу,**

камырга әйләнү — нинди дә булса сәбәп аркасында хәлсезләнү, буыннар йомшау.

КАМЫРЛЫК *и.* Камыр агачы күп үскән урын. *Икенче бер урында камырлыкка туры килдек.* Ә. Баянов.

КАМЫРЛАНУ *ф.* Камырга буялу. — *Гаеп итмәгез, кунаклар, кулларым бик камырланган, мич сүрелгәнче тизрәк өлгертим дип, бәлеш ясый идем.* М. Гали.

КАМЫРЛЫ *с.* Камырга буялган. *Марат камырлы кулын пычак белән кыра-кыра чыгып килгән Зифага әз генә баш иеп алды да - - - сабыйларча уйнаклап, пар атка каршы йөгерде.* Г. Гобәй.

КАМЫТ *и.* 1. Ат муенына кидерелә торган җигү әйбере. *Юкә такта белән икегә бүленгән бу өйнең бирге өлешендә иске сандык, чөлдерексез камыт, ярты тубал солы аунап ята.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Күп көч куюны сорый торган берәр эш, мәшәкать һ. б. [*Сестра*] *революция юлында хезмәт итә. Революцион сугышның авыр камытын өстери.* А. Шамов.

Камыт бавы — камытка тәртә һәм дуганы беркетеп куя өчен хезмәт итә торган күн әлмәк. *Пычрак, тайгак, күперләр бозык, юл саен диярлек камыт бавы, тәҗе өзелеп, арба ватылып теңкәне корыта.* Г. Ибраһимов. **Камыт сугу (тию)** — ат муенын камыт белән кырдырып чиләндерү. [*Мөршидә:*] *Ни булган соң җирән кашкага?* [*Ишнияз:*] *Камыт суккан.* Р. Ишморат. **Камыт энәсе** — күн һәм калын тупас тукымалар тегү өчен кулланыла торган махсус зур энә. *Әгәр дә ясау-нитү кирәк булганда, әнә камыт энәсе, без дә, җеп очы да, каеш та шунда.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

◇ **Камыт аяк (сыйрак)** — тез һәм балтырлар бербөтен ерагаю рәвешендәге кәкре аяк (кеше турында). *Ә плащ эченнән француз белән галифе кигән, кылыч борынына пенснэ элэктерелгән ач яңаклы камыт сыйраклы Дәүләтъяровны ул әле беренче тапкыр гына күрә иде.* И. Гази. **Камыт кию** — авыр эшкә алыну, җаваплылыкны үз өстенә алу. *Организаторлык камытын кидеңме инде, һәммәсен истә тотарга тиешсең.* М. Максуд.

КАМЫТЛАНУ *ф.* Камытка охшау, камыт рәвешен алып кәкрәю. *Камытланып килү. Камытланып торган аяклар.*

КАМЫТЛАУ *ф.* Камыт кидерү. *Ул торганда - - - әтисе, арбаны майлап бетереп, атны камытлый иде.* М. Гафури.

КАМЫТЛЫ *с.* Камытланган, камыт кидерелгән, җигүле. [*Атны*] *начхозга алып барып, расписка белән тапшырдылар, камытлы атлар янына бәйләп куйдылар.* А. Шамов.

КАМЫТЧЫ *и.* Камыт ясаучы, камыт ясау остасы. *Хәдичә, - - - камытчы Бәдретдин дигән кешенең бердәнбер сөекле кызы.* С. Рәмиев.

КАМЫТ-ЭШЛЕЯ *җыйд. и.* Камыт, эшлея һ. б. җигү кирәк-ярагы. *Җәйгә чыкса* — [*бабай*] *әле кемгә булса арба төзәтә, әле камыт-эшлея төзәтә, әле бау ишә иде.* Г. Гали.

КАМЫШ *и.* 1. Сазлыкларда үсә торган кыяклы биек үлән үсемлек. *Утраулар куе соры тал һәм киң-киң кыяклы камышлар белән капланганнар.* М. Әмир. *Күлне сыйпап җил исә, Тирбәнеп камыш үсә.* Ф. Кәрим. || *с. мәгъ.* Камыштан ясалган, камыштан эшләнгән. *Карт сәкегә җәелгән камыш палас өстенә уңайлабрак утырды.* А. Шамов. *Кичен* [*Гөлсем апаның*] *мәктәптән кайтуына, бәрәңге камыш сумка белән аралыктагы чөйдә тора иде.* Г. Гобәй. || Камыш белән ябылган, капланган. *Камыш түбә.*

2. *к.* камышлык. *Камыштан чыгуы бик кыен булды.* И. Гази.

3. *с. күч.* Зифа, төз (кеше гәүдәсе турында). *Ялтыр кара чәчле, тулы канлы, камыш буйлы бер егет, кулындагы камчысын уйната биреп, көлә-көлә нидер сөйли иде.* Г. Ибраһимов.

Камыш кирпеч — *к.* камышит. **Камыш тургае, камыш чыпчыгы** *зоол.* — камыш арасында һәм яр буе куаклыкларында яши торган сайрар кош.

КАМЫШИТ *и. махс.* Камыштан ясалган төзү материалы (гипс, балчык һ. б. ш. нәрсәләр кушып пресланган плиталар).

КАМЫШ-КҮРӘН *җыйд. и.* Камыш һәм шуңа охшаш кыяклы үләннәр. *Күл тирәсендә кара-кучкыл тора камыш-күрән, Ул болыннар туп-тулыдыр төрле төстә төрле үлән.* М. Гафури.

КАМЫШЛЫ *с.* Камышы булган, үзендә камыш үскән. *Кайбер урыннарда өерле таллар арасында кечерәк кенә камышлы күлләр дә күренеп алалар.* М. Гали. *Сибай камышлы вак-вак утраулар арасыннан борып-сарып* [*көймәне*] *җиңел генә алып бара.* А. Гыйләҗев.

КАМЫШЛЫК *и.* Камыш (күп) үсә торган урын. *Миус* [*елгасы*] *буендагы камышлыкларга кадәр траншея казылды.* И. Гази.

КАМӘТ *и. иск.* 1. Гәүдә, буй-сын. *Кайда китте бу озын, аристократический бөгелә-сыгыла белә торган фигураң (камәтең).* Ф. Әмирхан.

2. *дини.* Намазга керешү алдыннан аяк үрә укыла торган дога.

Камәт төшерү *дини* — намазга кереш ясау. *Камәт төшереп, „әлхәм“ укый башлауга, ишеккә каршы нар өстеннән - - - карт солдатның тавышы килде.* К. Нәҗми.

КАН *и.* 1. Организмда тамырлар буенча хәрәкәт итә торган кызыл сыекча (тәннең күзәнәкләрен туендырып, матдәләр алмашуны тәэмин итә). *Шинель җиңе эченнән кайнар кан ага башлады.* Ә. Айдар.

2. *күч.* Бер каннан — бер ана яки атадан булу белән бәйләнешле якын туганлык турында. *Күрәсең, миндә әле булса шул ата-баба каны үзен сиздерәдер.* Н. Фәттах.

3. Малларның килеп чыгышы, токымы турында. [*Совхозда*] *- - - менә дигән холмогор үгезләр, яхшы нәсел, таза кан айгырлар бар.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Сугыш кырында көрәшеп үлү; үлем. *Салават мәңге сәламәт! Каны безгә — эманәт, китермәбез яман ат.* Ш. Бабич.

Кан кардәш — нәселдәш, туган. — *Мин дә бераз булышкан идем. Кан кардәш бит.* К. Тинчурин. **Кан кызыл** — бик нык кызыл, ачык кызыл. **Кан күрү** — *к.* күрем. **Кан (басымы) күтәрелү** — *к.* гипертония. *Бибиҗамал апа - - - башым чатнап тора, каным күтәрелгән ахрысы дип, сүзне йомгаклап куйды.* Ш. Хөсәенов. **Кан тамыры** — кан йөри торган юл. [*Алмаевның*] *колак яфракларындагы нечкә кан тамырлары, кып-кызыл булып, үтәли күренеп тораллар.* И. Гази.

◇ **Кан агулау** — *к.* кан бозу. *Ник сызлыйсың, күңлем? Ник юк өчен Агулыйсың минем каныңны?* Ш. Бабич. [**Күзне**] **кан басу** — ачудан, бик нык ярсудан бернәрсә дә күрмәс хәлгә килү; күзләр томалану. *Безнең күзләрне кан басты.* Г. Гали. **Кан бозу** — 1) ярсу, кәеф бозу. *Кичә* [*Тәзкирәгә*] *үз бригадасындагы кайбер кешеләр белән әчелешле булырга, каның бозарга туры килгән иде.* Ф. Хөсни; 2) ярсыту, кәефен бозу. — *Әй син миңа эшләргә ирек бирмисең, минем канымны бозасың.* Ш. Камал. **Кан бутау, катыштыру** — башка милләт кешесе белән өйләнешү. — *Чөнки алар урысы-татары, чувашы-керәшене бергә буталып, кыз биреп, кыз алып кан катыштыралар.* Г. Бәширов. **Кан дошманы** — бик нык дошман кеше турында. *Кан дошманнарыңны нык хәтерлә, һичбер*

вакытта да онытма! Ә. Ерикәй. **Кан елау** — зур кайгыдан, хәсрәттән елау; бик әрнеп елау. *Соңыннан гомер буе күз яше түккәнче, бер тапкыр кан елау хәерлерәк.* М. Хәсәнов. **Кан имү** — *к.* кан эчү. **Кан йоту** — бик нык борчылу; тирән кайгы кичерү. — *Я инде, илаһым, боларның миндә ни эше бар икән?!* — *дип, кан йота* [*Мәрьям*]. Г. Ибраһимов. **Кан йөгерү (бәрү)** — 1) кан тамырлары шартлап, тәннең бер урынына күпләп кан җыелу. [*Фатыйманың*] *йөзендә кызгылт таплар күренә, күзләренә кан йөгергән иде.* Ш. Камал; 2) *мед.* баштагы кан тамырларының шартлавы аркасында мигә кан җыелу, таралу. *Сәхип солдат соңыннан ишанның бу кинәт үлемен „башына кан йөгерү“дән булган дип аңлатты.* Ә. Фәйзи. **Кан кайнау (уйнау)** — 1) ярсу, кызып китү. *Хәдичә каны кайнавын тойса да, ачуын эчкә йотарга булды.* М. Хәсәнов. *Фәйзулланың ачудан каны уйный башлады.* Ф. Хөсни; 2) дәртләнү. *Каннары кайнаган чакта рәхәтләнеп җырлап җибәрү аның кузгалган күңелен баса.* Г. Галиев. *Күкрәккә мул булып ургылып кергән җиләс саф һава канны уйнатып тәнне җиңеләйтә.* Г. Бәширов. **Кан кату** — 1) артык нык куркып катып калганда була торган тойгы турында; 2) бик нык ачу килү, рәнҗү, күңел кату, гафу итә алмау турында. [*Башкирцев*] *атасы гражданнар сугышында үлеп калгач, революция дошманнарына карата каны катып, --- канлы көрәш юлына кереп киткән.* М. Әмир. **Кан качу** — каты курку, ачу яки берәр төрле авыру аркасында йөз-иреннәрнең агарып, күгәреп китүе турында. *Аның йөзеннән кан качты; борыны очланып калды.* И. Гази. **Кан корыту** — *к.* теңкәгә тию. — *Кайткач, тотып каезлармын әле менә үзен, бик канымны корытса* [*дип уйлады Фатих*]. Р. Төхфәтуллин. **Кан кою (түгү)** — 1) үтерү; 2) сугышу, сугышта катнашу, яралану. *Син ил өчен, безнең өчен кан коеп, имгәнеп кайттың.* Р. Ишморат. *Без — тезләнә торган нәсел түгел, Без бәйсезлек өчен кан түктек.* Ә. Ерикәй. **Кан коюлы** — *к.* канкойгыч. *Кан коюлы сугышлар.* **Кан кызу** — ачу килү. *Мәүлиха түтинең* [*Әпипәгә*] *күптән үк каны кызып утыра иде.* Г. Бәширов. **Кан саву (савылу)** — берәр урынга кан җыелу. *Операция барышында тагын Юматшаның --- үпкә ярысы ертылып, үпкәсенә кан савылуы беленде.* Г. Әпсәләмов. **Кан тарату** — кан хәрәкәтен, йөрешен көчәйтү, активлаштыру. — *Тик аякларыгызның канын таратып алсагыз, кайтырга җиңелрәк булыр иде.* М. Фәйзи. **Кан тарту** — якын итү, туган итү. *Җан тартмаса, кан тарта.* Мәкаль. **Кан эчү** — 1) бик нык җәберләү, мыскыл итеп яшәү; 2) изү, эксплуатацияләү. — *Байлар безне суткасына 16-17 шәр сәгать хезмәт иттереп, каныбызны эчәләр.* Ш. Мөхәммәдев. **Кан ягу** — каныгу, үчегү. *Авылга керү белән этләре дә теләнчегә каннарын ягалар тагын.* Г. Толымбай. **Канга бату** — сугышып яки кыйналып бик нык канга буялу. *Я винтовка тотәсе белән сукканнар булса кирәк, авыз-борыны канга баткан.* А. Шамов. **Канга буялу (куллар)** — кеше үтерү турында. **Канга сеңү** — нык урнашу, гадәт булып китү. *Ашау белән өс-баш кайгыртудан башкасы* [*этинең*] *канына сеңмәгән.* С. Рафиков. **Канга тоз салу** — хурлап, кимсетеп, явызлык эшләп рухи газаплау. *Зәмзәмбикә нахак сүзләре белән бик нык теңкәгә тиде, каныма бик күп тоз салды.* М. Хәсәнов. **Канга тузу** — *к.* канга бату. *Канга тузып ята юл чатында Бер өч яшьлек бала гәүдәсе.* М. Җәлил. **Канга төшү** — үзәккә үтү, тәмам туйдыру. *ГЭСны төзеп бетергәннән бирле, менә елдан артты инде.* [*Федор Иванович*] *тәмам каныбызга төште.* А. Гыйләҗев. **Канын сыгу** — *к.* кан эчү.

КАНА [қана] *кис. сөйл.* Ләбаса, бит, ич. *Күп торасы да бит кана, күптән аякка басасы, йөрәк бик чуар.* Г. Бәширов. — *Бер дә табалап та әйтмим кана, бары, Рокыя белән булышканыңа гына кәефем китеп әйтәм дә.* Ф. Әмирхан.

КАНАЛ *и.* **1.** Елга, күл яки диңгезләрне үзара тоташтыру, шулай ук су белән тәэмин итү, сугару һ. б. эшләр өчен казып ясалган тирән, киң чокыр, канау. *Ташый сыман саф су каналларда Кибеп яткан иркен сахрага.* Ш. Мөдәррис. *Бу болын әлек сазлык иде, Бу каналлар әлек юк иде.* М. Җәлил.

2. *тех.* Көпшә куышлыгы (мылтык көпшәсендә һ. б. ш).

3. *анат.* Кеше яки хайван организмындагы теге яки бу матдәләрне үткәрә торган юл. *Ашкайнату каналы.*

КАНАЛИЗА'ТОР *и.* Канализация эшләре белгече.

КАНАЛИЗА'ЦИЯ *и.* Шакшы суларны агызу өчен кулланыла торган торбалар, җир асты каналлары һәм башка санитар-техник корылмалар системасы. *Йортны. канализациягә тоташтыру.*

КАНАЛИЗАЦИЯЛӘҮ *ф.* Канализация үткәрү.

КАНАТ *и.* Сүстән яки тимер чыбыктан кат-кат ишелгән калын, нык бау. *Канатта биюче.* □ *Ул чаналарга зур-зур насослар, корыч канатлар --- төялгән.* М. Хәсәнов.

КАНАТ [қанат] *и.* **1.** Очу органы (кошларда, бөҗәкләрдә һ. б.). *Бал корты очып китәргә дип канатларын җәйлады.* А. Алиш. [*Казлар*] *бик яман каңгылдашалар һәм киерелеп-киерелеп канат кагыналар иде.* Ә. Еники. || Кошлардагы шул органның идән себерү өчен файдаланыла торган өлеше. [*Бәдигылҗамал*] *канат белән комод артындагы хатны себереп чыгара.* Г. Камал. || Таба ашларын майлау өчен җыеп бәйләнгән әре каурыйлар. [*Бәлешнең*] *өстен канат белән майлыйлар да кайнар мичкә яки духовкага тыгалар.* Азат хатын. || *тарт. форм.* **Канатым.** Ярату, иркәләү һәм ихтирам хисләре белән әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Әпипә: Ай, канатым, Мәүлиха түти, бигрәк тә юкка әрнисең.* Г. Бәширов.

2. Балыкларның суда хәрәкәтләнү органы. *Күз алдымда кызыл канатларын кабарткан, авызын ачкан алабуга торса да, сүзем икенче булды.* А. Әхмәт.

3. Самолетның як-ягына урнашкан кош канатына охшаш яссылыклар. *Канатын җәеп, берничә самолет басып тора.* Ә. Исхак. *Авиатехник канаттан тотып, селкеткәләп, чаңгылары белән җепшек карга ябышкан самолетны кузгатып җибәрде.* С. Баттал.

4. Үрәчә (чанада). *Чана канаты төпкә эләкте.* И. Туктар.

5. Җил тегермәне чарыгындагы әйләнә торган калак. *Ерактa кара җир белән зәңгәр күк тоташкан урында, җил тегермәненең канатлары әкрен генә әйләнә.* И. Гази. || Комбайнда, урак машинасында ашлыкны кискечкә юнәлдерә һәм урылган ашлыкны өем-өем итеп читкә ташлап бара торган калак. *Мостафа, лобогрейка канатлары астына җыйнала торган солы кисенделәрен кулындагы агач сәнәге белән бертуктаусыз почмакка тартып, өемнәр ясый.* Ш. Камал.

6. Су һәм пычрак чәчрәүдән саклау өчен тәгәрмәч өстенә аска таба колашаландырып урнаштырылган калай япма (автомобиль, велосипед һ. б. ларда). *Машинаның канатына басып, Җилгә куеп егет күкрәген, Җилкәсенә автоматын асып, Бара тыңлап туплар күкрәвен.* Ш. Маннур.

7. Капка, тәрәзә, шкаф һ. б. ш. ике якка ачылмалы капкачлары. *Сәлмән үзе капканың бер канатын ачып, икенчесен ачарга өлгерә алмый калды.* Ф. Хөсни. *Тәрәзә канатлары ачылып киттеләр.* М. Гафури.

8. Нәрсәнең дә булса ян өлеше яки бинаның ян корпусы; флигель. [*Мәдинә*] *ферманың эченә керде. (Бу — ферма бинасының бер як канаты гына иде.)* М. Хәсәнов.

9. *хәрби.* Хәрби сафлардагы гаскәрләрнең оператив төзелешендәге уң яки сул як өлеше. *Уң канаттагы беренче ротаның командиры --- үзенең солдатларын җыйды да, аларны икегә аерганнан соң, бер взводы белән үзе уң якка таба китте, икенче взвод сул якка таба юл тотты.* С. Җәләл. *Шәмси белә иде инде: ул киткәннән соң, аның полкын фронтның әле бер канатына, әле икенчесенә ташлаганнар.* Г. Бәширов.

10. *полит.* Нинди дә булса политик оешманың, партиянең уң яки сул группировкасы. *Мифраннар, тагы шундый мәдрәсәдән чыкмый калган кара уң канат шәкертләр бу җыелышта да идарәләрне яклап азапландылар.* Г. Ибраһимов.

11. *күч.* Таяныч, терәк. — *Мин нишләп ялгыз булыйм? — ди. Минем канатым — колхоз.* Н. Исәнбәт. *Очкын коштай синең туры атың, --- Хыянәтсез дустың, канатың...* Һ. Такташ.

◇ **Канат астына алу** — яклау. — *„Җәүдәт абый, бодаебызны канат астыңа алсана!" — диясе иде.* Г. Бәширов. **Канат астына керү** — кемнең дә булса яклавында, тәрбиясендә булу. *Назлы, иркә килен Гыйззелбанат та каенанадан котылды, үз анасының канаты астына кереп яши башлады.* Г. Ибраһимов. **Канат бирү** — көч бирү, илһам бирү. *Ил бирде миңа нык канат һәм сүнмәслек дәрт.* Ә. Исхак. **Канат кагу** — шатлану, куану. *Мин китсәм, кемнәр канат кагачак? Галәү ияреннәре.* Г. Ахунов. **Канат салындыру** — төшенкелеккә бирелү. — *Ә син юкка гына канатларыңны салындырасың, Зариф ипташ.* Ш. Камал. **Канат сыну** — ышаныч, көч һ. б. бетү, югалу. *Бераздан зоотехник шактый тынычланды, чөнки Ифратның канатлары сынмаган иде.* А. Расих. **Канат чыгу** — 1) нинди дә булса эшне эшләргә мөмкинлек ачылу, дәрт, илһам туу; 2) үзбашына яши, эшли алырлык хәлгә килү. **Канат яру** — 1) *к.* канат чыгу 2) — *Канат яргачыннан кош та баласын очыра.* Г. Бәширов; 2) үсеп житү, балигъ булу. *Күрәсең бит — җыен яшь-җилбәзәк. Аларның бригадирлары да әле яңа гына канат ярган нәрсә бит!* А. Расих. **Канат үсү** — 1) рух күтәрелү, дәртләну. *Хат йөрәккә яңа көч бирә һәм күңелгә канат үстерә.* Ш. Маннур; 2) көч арту, көчләнү. [*Аклар*] *килсә, Маликка тагын канат үсә инде.* И. Гази. **Канат җәю** — 1) каплап алу, зур мәйданга таралу. *Яктылык сүнә, әзәя, карангылык үзенең канатын җәя.* А. Алиш; 2) кыю рәвештә эшләү, хәрәкәт итү. *Пионерлар да җәйделәр канатларын, алар, колхозчылардан күрмәкче, тирес өемнәренең кар астыннан чыкканын берән барып тараттылар.* Г. Гобәй. **Канатын каеру** — кемнең дә булса көчен, эшчәнлеген, мөмкинлеген бетерү, теләк-омтылышларына чик кую. *Канатлары каерылса да бирешмәсләр, аларны инде бездә арслан егет диләр.* А. Шамов.

КАНАТЛАНДЫРУ *ф.* Дәртләндерү, рухландыру. *Авылга кайтканнан бирле алып барылган эшебезнең нәтиҗәсен бөтен авыл каршында ачык күрсәтү дәрте канатландыра иде безне.* М. Әмир.

КАНАТЛАНУ *ф.* 1. Канат чыгу, канат үсү, оча башлау (кошлар турында). | *күч. Аргамагым, әйдә, канатлан да Җил булып оч сугыш кырына!* М. Җәлил.

2. *күч.* Дәртләну, рухлану. *Эш тансыклаганга, ахрысы, ул бу көннәрдә аеруча җанланып, канатланып китә.* Ә. Еники. *Нәфисә бригадасының уңышлары белән канатланып, Карлыгач, үзе эш күрсәтергә дәртләнеп йөри башлаган иде.* Г. Бәширов.

КАНАТЛЫ *с.* Канаттан эшләнгән, канат буйлап йөри торган. *Канатлы юл.*

КАНАТЛЫ [қанатлы] *с.* 1. Канаты булган, оча торган. *Кыйбла якка вакытлыча киткән канатлы кунаклар үзебезгә кайталар.* Г. Туқай.

2. *күч.* Ашкынучан, омтылучан. *Йолдызлар белән бизәлде, бизәлде күз алларым; Каз юлы буйлап очтылар Канатлы хыялларым.* Ф. Кәрим. *Күңел бит, күңел, — Җитез канатлы. Әллә кайларда йөртә Айратны.* З. Мансур.

◇ **Канатлы чана** — *к.* үрәчәле чана. **Канатлы сүз** — 1) авторы яки чыганагы билгеле булган әйтем, афоризм. *„Муллык мөгезе", „Карфаген җимерелергә тиеш" дигән канатлы сүзләр инде телебезнең тиешле стиендә үзләшеп киткәннәр.* С. Фәйзуллин; 2) гомумкулланышка кергән үткен, тапкыр, сәнгатьле сүз яки фраза. *Солтан Сабиров, кыска, әмма җылы, канатлы сүзләр белән митингны ачкач, беренче сүзне --- Никитинга бирде.* С. Рафиков. **Канатлы җөмлә** — тапкыр, үткен, оста әйтелгән җөмлә. *Канатлы җөмлә яшен тизлеге белән бөтен мәктәпкә таралды.* Г. Кутуй.

КАНАУ *и.* Артык тирән итмичә казылган озын, тар чокыр. [*Нәсимә:*] *Ул канау труба төшерер өчен, нефть агызыр өчен кирәк икән.* А. Әхмәт. *Агачлар, түбәләр, урамнар, тротуарлар яңгырдан чыланып ялтырыйлар, канаулардан шалтырап сулар агарга тотына.* Г. Ибраһимов.

КАНАУ [қанау] *ф.* Кан чыгу, кан агу. *Фатыйма, битләре канап беткән Хәлимне күргәч, коелып төште.* И. Гази. *Газизә --- кызганган тавыш белән: — Гариф абзый, нишләдең болай? Битең каный ич!* Ш. Камал.

КАНВА *и.* 1. Тапкырлап чигү өчен кулланыла торган крахмаллап эшләнгән челтәр сыман сирәк тукыма. *Ак мамык киндергә канва белән затлы бизәкләр, әтәч сурәтләре чигелгән --- озын сөлгене солдатлар, өй әйбере итеп, кызыксынып карыйлар.* Ф. Хөсни.

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса нигезе. || Әсәрнең төп сюжет линиясе. *Күп вакытта мөхәррир тарихи дөреслектән бигрәк, әдәби дөреслекне алга сөрә вә тарихи вакыйгаларны үз гәрләренә канва итеп кенә ала.* Ф. Әмирхан.

КАНДАЛА *и.* Кеше каны белән тукланучы паразит бөҗәк. *Миңа, өй эче бөркү булу өстенә, таракан, кандалалар төрле яктан һөҗүм итә башладылар.* М. Гафури. *Кандалалар белән борчалар [Хафизны] үрле-кырлы сикертәләр бугай.* Г. Камал. || Судагы яки урмандагы паразит бөҗәк. *Урман кандаласы. Су кандаласы.*

Кандала үләне *бот.* — нык тармакланып үсүчән, ак яки сары чәчәк ата торган начар исле үсемлек (кандала бетерү өчен кулланыла). *Ачыклыктагы кандала үләне ачы җилдә чайкала.* А. Расих.

◇ **Кандала оясы** — кандаласы күп булган бүлмә яки мебель.

КАНДАШ *с.* 1. Канын бирүче (кан алучы); бертуган. [*Хәйруллин*] *бит минем кандаш энем.* Ә. Айдар.

2. Рухи яктан нык бәйләнгән. *Тукай кешелекле интеллигенциянең кандаш туганы булды.* Г. Халит.

КАНДИ *и. а.-х.* — Бал кортлары өчен, балга шикәр пудрасы кушып, помадка кебек хәзерләнгән азык. *Корт анасы казаннарын читлеккә урнаштыру вакытына кәнди дип атала торган махсус азык әзерли.* Умартачылык.

КАНДИДАТ *и.* 1. Кая да булса сайланырга, җибәрелергә яки кабул ителергә, нәрсә дә булса алырга билгеләнгән кеше. *Депутатлыкка кандидат.* □ *Шул ук кичне без Харрасны партиягә кандидат итеп тә алдык һәм мин Гөлнарга хат та яздым.* Ә. Айдар. *Ләкин бу яңа разведчикның тышкы кыяфәте күбесенә*

ошамады, һәм аның зәңгәр конверткә кандидат була алуын алар башларына да китермиләр иде. А. Әхмәт.

2. Диссертация яклаучыга бирелә торган иң түбән гыйльми дәрәҗә, шулай ук бу дәрәҗәне алган кеше. *Кайда күргәнең бар синең завод лабораториясендә фән кандидаты утырганын?* Э. Касыймов.

КАНДИДАТЛЫК *и.* Кандидат булу. [*Степан Гаврилович:*] *Бөтен мөһим нәрсәләр турында язып барыгыз. Бу сезгә киләчәктә, кандидатлыкка диссертация язган чакта кирәк булыр.* Г. Әпсәләмов.

КАНДИДАТУ'РА *и. к.* кандидат 1. [*Совхозга җибәрү өчен*] *шулай ук кандидатуралар да күрсәтелде.* М. Хәсәнов. *Иң элек исемлеккә кергән барлык иптәшләрнең фамилияләрен ишетик. Аннары һәр кандидатурага аерым тукталырбыз.* С. Рафиков.

КАНДИЛ *и.* Берничә шәм яки электр лампочкалары куела торган зур шәмдәл. *Күп санлы электрик кандилләре белән яктыртылган залдан кемнәрнеңдер тигез вә ачык тавыш белән русча сөйләшкәннәре ишетелә иде.* Ф. Әмирхан. *Түшәмгә берничә шәмле кандил эленгән.* М. Фәйзи.

КАНДИЛЬ *и. бот.* Озынча формалы, сусыл алма бирә торган алмагач сорты.

КАНЕЧКЕЧ *с.* Мәрхәмәтсез, каты күңелле, кансыз, явыз. *Канечкеч Галкәйнең кушуы буенча, башыма дымлы кәҗә тиресе каплап, урам буйлата рисвай итеп йөрттеләр.* Ш. Камал. *Бетсен канечкеч палачлар!* М. Гафури. | *и. мәгъ. — Дуслар, — диде [Рәхимов] безгә карап, — әгәр сез мине якын күрәсез, дус итәсез икән, минем мыскылланган, хурланган мәхәббәтем өчен дә үч алыйк без ул канечкечләрдән!* А. Шамов.

КАНИ'КУЛ *и.* Мәктәптә, уку йортларында укуларның тукталып тору вакыты. *Газиз, җәйләрен каникулга кайткач, „Чулпан"да агротехник булып эшли башлаганнан бирле, иген эшләре дә әллә ничек бик үзгәреп китте.* Г. Бәширов. *Җәйге каникул вакытында авылыма кайттым.* М. Әмир. || *тар.* Парламент эшендә тукталып тору вакыты.

КАНИ'СТРА *и.* Бензин, керосин һ. б. лар салу өчен герметик капкачлы бак. *Бер солдат йөгереп барып машинадан канистра алып килде.* Н. Дәүли. *„Рәүф запас канистраларны онытып калдырмаган булса, бәлки, барып та җиткән булыр идек",— дип уйлыйм.* Р. Батуллин.

КАНИТЕЛЬ *и. сөйл.* Чуалчык, буталчык, четерекле эш. [*Госман*] *эшенә, заводның үзәк лабораториясенә барса, тагын канитель.* Э. Касыймов.

КАНИФАС *и.* Үзеннән бизәк чыккан киже-мамык тукыма. *Күлмәклек канифас.*

КАНИФОЛЬ *и. махс.* Ылыслы агачларның сумаласын куып алына торган уалучан, пыяла сыман матдә (промышленностьта изоляция һәм җилем итеп, шулай ук кыллы уен коралларының смычокларын ышку өчен кулланыла); сәмих.

КАНИФОЛЬЛӘҮ *ф.* Канифоль, сәмих сөртү, канифоль белән ышку. *Дәүли бабай ашыкмыйча гына смычогын канифольли, берәүгә дә карамый гына скрипкасын чирткәләп рәтли.* А. Әхмәт.

КАНКАН *и.* Гәүдәне төрлечә әдәпсез хәрәкәтләндереп бию, француз эстрада бию е.

КА'НКОЙГЫЧ *с.* Кан коела торган, күп кан түгелә торган. *Канкойгыч сугыш.*

КАНЛАНУ *ф.* Канга буялу, кан белән пычрану. [*Тимер кендекнең*] *нечкә башы бөтенләй кара канланып каткан иде.* Г. Ибраһимов. || Кан басу, кан каплау. *Кайгылардан күрче Канланды күземнең алмасы.* Һ. Такташ.

КАНЛЫ *с.* 1. Канга буялган, канланган. *Биргәнне дә көтмичә,* [*Газизә*] *Гарифның канлы яулыгын кулыннан алып диңгез кырыена йөгерде.* Ш. Камал. || Кан катыш, кан белән. *Канлы эч китү.* □ [*Атның*] *ялларын җил тузгыта, авызларыннан канлы күбекләр оча.* Г. Әпсәләмов. || Кан агып торган, кан саркып торган (яра һ. б. лар турында). *Габдрахман --- яңагындагы яулыкны чишеп, канлы яраны күрсәтте.* Г. Ибраһимов.

2. Үтерешү, күп кешеләр һәлак булу белән бара торган (сугыш һ. б.). *Хәзер Мансуров каршында канлы сугыш юлларын, үлем эскәнҗәсен үткән егерме дүрт яшьлек ир кеше — фронт офицеры утыра иде.* Г. Бәширов. *Полиция белән канлы бәрелешләр булган.* Ә. Фәйзи. || Күп кан түгелүгә, күп корбаннарга сәбәпче булган. *Гүя ки, --- ата-бабаларын ризыкландырган, хәзер үзләрен, газиз балаларын ризыкландырып килүче --- мөкатдәс туфракларына да басты канлы Гитлерның канлы итеге.* Г. Гобәй.

Канлы якшәмбе *тар.* — 1905 елның 9 январенда патша Петербургта эшчеләрнең тыныч демонстрациясен аттырган көн. *Санкт-Петербургтагы канлы якшәмбе бөтен илне тетрәтте.* А. Расих.

◇ **Канлы яшь** — көчле кайгы кичереп бик нык әрнеп, ярсып елау турында. *Һаман көлеп йөргән зур күзләрен Канлы яшьләр белән тутырды.* Һ. Такташ.

КАННИБАЛ *и. кит.* 1. Кеше ашаучы, вәхши кеше. 2. *күч.* Чиктән тыш рәхимсез, ерткыч кеше. *Бел, каннибал, сиңа туры килер Җир астында бездә кышларга.* М. Җәлил.

КАНОНА'ДА *и. хәрби.* Күп санлы артиллерия орудиеләреннән еш-еш ату һәм шуннан ишетелгән гүләү тавышы. *Канонада тавышыннан колаклар тонды.* Э. Айдар.

КАНОНЕ'Р: канонер көймә — *к.* канонерка. *Канонер көймә танкерга ут ачты.* Г. Әпсәләмов.

КАНОНЕ'РКА *и. хәрби.* Уртача калибрлы артиллерия орудиеләре белән коралландырылган хәрби диңгез судносы. — *Штабс капитан әфәнде, иртәдән бирле кызылларның ике канонеркалары кичүдәге ротабызны борчыйлар.* Т. Гыйззәт.

КАНОНИК *и. дини.* Католик соборындагы рухани.

КАНОНИР *и. тар.* XIX йөздә Россиядә артиллерия солдаты, тупчы солдат. *Канонирлар аттылар да аттылар. Тавыштан колаклар тонды.* Каз. утл.

КАНО'Э *и. спорт.* Беркетелмәгән кыска ишкәкле җиңел спорт көймәсе. *Каноэ — кыска ишкәкле җиңел спорт көймәсе. Төньяк Америка индеецларының чокып ясалган көймәсен элек шулай дип йөрткәннәр.* Г. Мөхәммәтшин.

КАНО'ЭЧЫ *и.* Каноэда йөрүче, ишкәкче. *Каноэчылар ярышы.*

КАНСУ *с.* Кан кебек, кан төсендәге. *Иң элек Камилнең күзенә ташланган нәрсә — иңеннән-иңенә кансу ал ут шәүләсе белән капланган офык булды.* М. Әмир.

КАНСУЛАНДЫРУ *ф.* Кансу төскә кертү. *Офык итәкләрен кансуландырып, моң гына булып кояш баеп килә.* А. Шамов.

КАНСУЛАНУ *ф.* Кан төсенә керү, кан кебек булу.

КАНСЫЗ *с.* 1. Каны аз, каны беткән; төссез. [*Зиннәтнең*] *кансыз иреннәре, ярым йомык күзләре баз салкынлыгы бәреп торалар.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Рәхимсез, кешелексез. *Бу Байтирәк абый бигрәк тә кансыз кеше икән, бераз гына кызганмый да...* Т. Гыйззәт.

КАНСЫЗЛАНУ *ф.* 1. Кан югалу, төссезләнү. *Йөзе кансызланып калган.*

2. *күч.* Рәхимсезләнү, кешелексезгә әйләнү. *Менә бит элек-электән шундый бер сүз бар: сугышта озак йөри торгач, кеше кансызлана башлый...* Г. Бәширов.

КАНСЫЗЛЫК *и.* 1. Кансыз булу, кан азлык.

2. *күч.* Рәхимсезлек, кешелексезлек. *Антонина йөргән юлдан бара, Аның торган өенә керә ул; Анда кансызлыкның актык чиген, Анда кан диңгезен күрә ул.* Ә. Ерикәй.

КАНСЫРАУ *ф. иск.* Бераз гына кан чыгып, кан күренеп тору; канланып тору. *Кыш суыкта без күшектек калтырап, Җәйге утта без пешектек кансырап.* Сов. әд.

КАНТ *и.* Күлмәк һәм форма киемнәренә тегелә торган гадәттә икенче төстәге тар гына тасма яки шнур. [*Габделхәйнең*] *өстендә чиккән күлмәк белән кызыл кантлы галифе чалбар.* Х. Гарданов.

КАНТАР *и.* Нинди дә булса каты әйбернең формасыз зур кисәге. [*Ибрай*] *үз сабаны каерып салган кантарга абынып китте.* Г. Гобәй. [*Кешеләр*] *вагонеткаларга әле күптән түгел генә шартлатып иштерелгән гипс кантарлары төйиләр.* А. Расих. *Зур-зур боз кантарлары тоташ масса булып ишелеп агыла.* С. Сабиров.

КАНТАРЛЫ *с.* Кантарлары булган, кантарлардан торган, зур-зур кисәкле. *Кантарлы җир.*

КАНТА'ТА *и.* 1. *муз.* Солистлар, хор һәм оркестр өчен язылган зур күләмле тантаналы музыкаль әсәр. *Сюита, соната, квартет һәм симфония кебек инструменталь әсәрләр булган шикелле, җыр, романс, кантата, опера кебек текстка бәйләнгән әсәрләр дә күп иде.* М. Җәлил. *М. Мазуновның „Минем Татарстаным" исемле кантата кебек яңа, катлаулы җыр язуы мактауга лаек.* Н. Юзиев.

2. *әд.* Борынгы тантаналы лирик шигырь төре.

КАНТИЛЕ'НА *и. муз.* Салмак моңлы көй.

КАНТКОМ *и. тар.* Кантон комитеты. *Башкарма һәм кантком эшчеләренә ай буе волостьлардан кайтмаска --- туры килде.* И. Гази. — *Габитов турындагы карарның протоколын миңа бирерсез, мин кантком раславына бирермен, кантком — губкомга җибәрер, — диде* [*Жуков*]. Ш. Камал.

КАНТЛАУ *ф.* Кант тегү, кант тоту. *Күлмәк итәген кантлау.*

КАНТЛЫ *с.* Кант тотылган, кант тегелгән. *Кантлы чалбар.*

КАНТОН *и. тар.* 1. Кайбер дәүләтләрдә административ-территориаль берәмлек.

2. XVIII—XIX йөзләрдә Башкириядәге административ округ.

3. Татарстанда 1921—1926 еллардагы административ-территориаль берәмлек. [*Рәхмәтуллин*] *укуы беткәч, яңадан бераз эшләгән дә, Татарстанга кайтып, безнең кантон җир бүлеге мөдире итеп билгеләнгән.* М. Гали.

КАНТОНАЛЬ *с.* Кантон күләмендәге. *Франциядә кантональ сайлаулар --- Франция коммунистларының позицияләре ныгыганлыгын күрсәтә.* Соц. Тат.

КАНТОНЛЫК *и.* Кантоннар системасы, кантоннар идарәсе. *Башкорт җирләрендә кантонлыклар бетерелгәч тә, ул, гәрчә элекке байлыгы кимесә дә, элекке дәрәҗә китсә дә, һаман да бөтенләй егылудан ерак иде.* Г. Ибраһимов.

КАНТЧЫ *и. филос.* Кант философиясе тарафдары.

КАНТЧЫЛЫК *и. филос.* XVIII йөздә яшәгән немец философы Кант һәм аның иярченнәренең идеалистик тәгълиматы.

КАНУ *ф.* Басылу, канәгатьләнү (сусын, үч, ачу һ. б.). *Ерактагы су белән сусын канмый.* Мәкаль. — *Дистәгә якын фашистның башына җиттем, — ди Петров. — Барыбер үчем канмады әле.* М. Әмир. || *күч.* Игеннәр, жир һ. б. суга туенуы турында. *Яңгыр коя буразнага — шыптыр-шыптыр, Бодайларның сусыны кансын, күп тор, күп тор!* М. Җәлил. || *күч.* Тую, туену, житәрлек алу. *Бер заман илгә кайта балга каныпп* [*балкорты*], *Үз илен баллатуны алга алып.* Ш. Бабич.

КАНУН *и.* 1. *иск. дини.* Дини догма, шәригать законнары. *Бар канун, диннән азат күңлем минем, Ишетәсеңме?* Һ. Такташ.

2. *к.* закон. — *Атаң әмере канун безгә, Солтан.* Н. Исәнбәт. [*Байтирәк:*] *Ул динсез кяферләрне шәригать кануннары белән хөкем итәрбез.* Т. Гыйззәт. *Нажия әле институтта аңлап җитмәгән яшәү өчен көрәш канунын тормышның үзеннән укып белде.* Н. Дәүли.

3. Нинди дә булса кагыйдә: традицион, мәҗбүри булып саналган норма. [*Ангараның*] *асылдан асыл сыйфатлары — карап туймаслык матурлыгында яисә үзенә бертөрле канун белән яшәвендә түгел.* М. Хәсәен. *Рәсем кануннары буенча кешенең гәүдәсе сигезгә бүленә.* Каз. утл.

КАНУНИ *с. иск. кит.* Канунга бәйләнешле, канунга әйләнгән.

КАНУНИЯТ *и. иск. кит.* Законлылык.

КАНУНЛАШУ *ф. сөйл.* 1. Законлашу, закон көчен алу, рәсмиләшү.

2. Кагыйдәләшү, калыпка салыну. *Тукай көнчыгыш поэзиясенең канунлашкан формаларын үз уй-тойгыларының тарихын, хәрәкәтен күрсәткән сәнгать чараларына әверелдерде.* Г. Халит.

3. *күч.* Гадәткә керү, ныклап урнашу. *Шакирның сәер җавабы ир белән хатын арасындагы канунлашкан мөнәсәбәткә каршы булып яңгырады.* Г. Минский.

КАНУНЛЫ *с. сөйл.* Законлы, законга нигезләнгән; закон төсен алган, канунлашкан.

КАНУНЛЫК *и. сөйл. к.* законлылык. *Менә бу сыйфатлар билгеле бер канунлыкта Тукай шигырьләре күпчелегендә дә күренә.* Г. Нигъмәти.

КАНУНЧЫ *и. иск.* Закон, кануннарны яхшы белүче, аның һәр кагыйдәсенә формаль таянучы, формалист кеше. *Бик артык канунчы, формалист дип танылган рәис Биганов алдында --- карт адвокат ике шаһит турында каты бәйләнде.* Г. Ибраһимов.

КАНУНЧЫЛЫК *и. иск. к.* догматизм. *Абстракт идеяләрнең бер төркеме канунчылык, „тәкъдир"гә буйсыну кирәклек һәм „тәкъдир" канун хөкеменең өстенлеген күрсәтүне белдерсә --- икенче бер төркемә шуңа каршы көрәшне --- күтәреп чыга.* Г. Нигъмәти.

КАНЦЕЛЯРИСТ *и. сөйл.* 1. Канцелариядә эшләүче, канцелярияче.

2. Берәр эшне эшләүдә артык формальлек күрсәтүче.

КАНЦЕЛЯ'РИЯ *и.* Учреждениедә эш башкару бүлеге һәм шул бүлек урнашкан бүлмә. *Канцелярия ишеге төбенә чаклы ачык.* Г. Бәширов.

Канцелярия теле (стиле) — эш кәгазьләрендә генә кулланыла торган сүзләр һәм әйләнмәләр күп булган стиль. *Канцелярия стиле өчен рәсмилек, билгеле бер трафаретлык хас.* В. Хаков.

КАНЦЕЛЯРИЯЧЕ *и.* Канцелариядә эшләүче.

КАНЦЕЛЯРИЯЧЕЛЕК *и.* Эш йөрткәндә, берәр эшне эшләүдә артык, урынсыз формальлек.

КА'НЦЛЕР *и. тар.* Кайбер дәүләтләрдә югары дәүләт хезмәтендәге кешегә бирелә торган исем һәм шул исемне алган кеше.

КАНЧА *иск. сор. а.* 1. Күпме, ничә. *Канча сум?*

2. *рәв. иск.* Никадәр, ничаклы. *Канча тартсаң, и мөхәррир, сүзне чит тел сибенә, тел ясалмас, Гәр туган сүз ятмаса үз ибенә.* Дәрдмәнд.

КАНЫГУ I *ф.* 1. Юк-бар сәбәпләр белән бәйләнеп йөдәтү. — *Каныкмагыз әле, зинһар, шул Миңнулла абзыйга, — дип, Шәрифҗан Миңнулланы яклаган булды.*

И. Гази. || Кемне дә булса дошман күреп, ана бәйләнү. [*Дускаев:*] *Сез менә каныгу дисез. Мин бу сүзне болай аңлыйм: әгәр берәү берәүгә каныкса, ул аның ямаратын сатып йөри, аның һәр эшен кыек күрә, җай чыккан саен аңа бәйләнә.* Ә. Еники. || Берәр нәрсә белән йөдәтү. [*Саимәнең*] *беренче мәхәббәте уңышсызлыкка юлыккач, аңа кемнәр генә каныкмадылар.* К. Нәжми.

2. Берәр нәрсә белән артык мавыгу, шуңа бирелү. *Каныктың инде шул китабыңа! — дип куя Фатыйма* [*улына*]. И. Гази.

КАНЫГУ II *ф.* Кан төшү [күзгә], канлану. *Кулым бер дә дөрес язмый, каныкканга күзләрем.* Бәет. || Кан басу (күзне), ачу, ярсудан берни күрмәс хәлгә килү. *Котырган ул, күзе каныккан.* Б. Рәхмәт.

КАНЬОН *и. геогр.* Су белән ашалган тирән, тар үзәнлек. *Колорадо елгасының зур каньоны үзенең грандиоз күренеше белән гажәпкә калдыра.* Чит ил. экон. геогр.

КАНЮ'ЛЯ *и.* Төрле формалардагы һәм зурлыктагы металл, каучук, пыяла трубкалар. [*Рәхим*] *калкансыман бизгә канюля куйган.* А. Расих.

КАН-ЯШЬ *җыйм. и.* Тирән кайгы, авыр газап; җәбер. [*Бибкәй:*] *үзебез яратмаган кешегә өченче-дүртенче хатынлыкка бирәп, гөлҗимеш чәчәгедәй матур яшьлегебезне кан-яшь белән юдыралар.* Т. Гыйззәт.

Кан-яшь түгү — тирән кайгы, авыр газап, җәбер кичерүдән бик нык елау. [*Бибиҗамал апаның*] *кан-яшь түгәсе көннәре алда икән әле.* Ш. Хөсәенов.

КАНӘГАТЬ *хәб.* Риза, риза булу. [*Рәхим:*] *Сезнең аша ишетүемә дә канәгать.* Р. Ишморат. [*Сәлим:*] *Завод миннән риза булса, шушысына мин канәгать.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Ризалык, канәгатьлек белдергән. *— Ике бәрәнле сарык белән тышлы яңа тун, — диде мулла бик канәгать йөз белән.* А. Шамов.

Канәгать булу, канәгать итү (кылу) — булганына риза булу, артыгын таләп итмәү. *Канәгать итми бер капчык белән алган асыл ташка, Кызыкты карт бу кызның муенына тезгән бу алмаска.* М. Гафури. *Иям башны, тартам йөкне, Дөнья һаман да канәгать кылмый, Өстемә төягәннән-төйи бара Күтәрә алмаслык авыр йөкне.* Г. Камал.

КАНӘГАТЬЛЕ *с.* Канәгать булган, риза булган. [*Сиражетдин*] *каты гына итеп тамагын кырып, киемнәрен төзәтеп, үзенә канәгатьле бер кеше кыяфәтен биреп куя.* Г. Камал. || Канәгатьләнә белә торган; *киресе:* туймас, ачкүз. *Канәгатьле кешедә көнчелек булмас.* Мәкаль.

КАНӘГАТЬЛЕК *и.* Канәгать булу хисе. *Мин үземнең тәҗрибәсезлегемнән ояла башладым һәм, тыштан икеләнгән кыяфәт күрсәтеп, эчтән тулы канәгатьлек сизеп, алдымда торган рюмканы алдым.* М. Әмир.

КАНӘГАТЬЛӘНГӘНЛЕК *и.* Канәгать булу, канәгатьлек хисе. *Каюм һәм Әхмәтнең йөзләрендә дә канәгатьләнгәнлек әсәре чагылды.* Ш. Камал.

КАНӘГАТЬЛӘНДЕРЕРЛЕК *с. к.* канәгатьләнерлек. *Александр Сергеевичның бөтен сораганнарына канәгатьләндерерлек җаваплар бирә алдым.* М. Гали.

КАНӘГАТЬЛӘНДЕРҮ *ф.* **1.** Кемнең дә булса теләк, үтенечен һәм таләпләрен үтәү, тормышка ашыру. *Кулына бернәрсә тотып йөрәген канәгатьләндерә алырлык дәрәҗәдә уйнау өчен никадәрле эш кирәк.* Г. Ибраһимов.

2. Таләпләргә, сорауга җавап бирү, туры килү. [*Иргали:*] *Хәзер инде безне бу уку канәгатьләндермәс, яңача, русча өйрәнәсебез килә, — дидем.* Ә. Фәйзи. *Җавап Сәлимне канәгатьләндермәде.* Г. Гобәй.

3. Нәрсә дә булса җитәрлек күләмдә булу. *Ат башыдай гына алтын аларны канәгатьләндереп бетми, күрәсең.* М. Гафури.

КАНӘГАТЬЛӘНЕРЛЕК *с.* **1.** Нинди дә булса таләпләргә туры килерлек, начар түгел. *Канәгатьләнерлек эш күрсәтү.* □ [*Дубцова:*] *Минемчә, хәзерге көндә безнең эшләр бөтен яктан канәгатьләнерлек, ипташлар.* Ш. Камал.

2. Шактый тулы, җитәрлек; дөрес. *Укытучыларның сорауларына ул, бик үк яхшы булмаса да, канәгатьләнерлек җавап бирә бара.* А. Әхмәт. || Күңел булырлык, туярлык. *Галиәкбәр агай канәгатьләнерлек - - - закусканың булмавы бераз кәефләрен бозмыш.* Ш. Мөхәммәдев.

3. *и.* Түбән уңай бәяне белдерә торган билге (белем, тәртип һ. б. бәяләгәндә). || *с. мәгъ.* Уртача. *Хор саны һәм сыйфаты - - - канәгатьләнерлек дәрәҗәдә тора.* М. Җәлил. | *рәв. мәгъ.* [*Тимербай Чолабаев*] *дипломны канәгатьләнерлек яклады.* М. Гали. || *и.* Берәр оешманың отчетын тыңлаганнан соң, аның эшенә бирелә торган уңай бәя. *Парткомның эшен канәгатьләнерлек дип билгеләделәр.* Г. Ахунов.

КАНӘГАТЬЛӘНҮ *ф.* **1.** Канәгатьлек тою, кичерү, берәр нәрсәдән канәгать калу, риза булу. [*Галия:*] *Гомеремдә беренче тапкыр мин үземнең йөзем-кыяфәтем белән канәгатьләндем.* Г. Кутуй. [*Рәүфә анасы*] *белән янәшә бара һәм шуңа да канәгатьләнә.* А. Шамов. || *рәв. мәгъ.* Канәгатьләнеп, канәгатьлек белән, риза булып, теләп. *Мәдрәсәнең олы шәкертләре һәм хәлфәләр аны бик канәгатьләнеп, шаулашып каршы алдылар.* Ә. Фәйзи.

2. Булганы белән чикләнү, риза булу, артыгын таләп итмәү. *Фәкать каймаклы чәй эчү белән генә канәгатьләнеп, кояш батыр-батмастан йокыга яттык.* М. Әмир.

КАНӘГАТЬСЕЗ *с.* **1.** Канәгать түгел, риза түгел. *Ләкин үзалдына, үз башына дөнья көтеп, Алатауның туйлары эчендә кайнаган Мәрхәбә әле һаман канәгатьсез иде.* Г. Ибраһимов.

2. Туймас. [*Кыз картка:*] *Гажәп сезнең халык! Биграк канәгатьсез вә бик консыз.* М. Гафури.

КАНӘГАТЬСЕЗЛЕК *и.* **1.** Канәгать түгеллек, риза түгеллек. *Үз-үзеннән канәгатьсезлек Габдулланың эчен тырнады.* Ә. Фәйзи.

2. Туймаучанлык, туймас күз булу, комсызлык.

КАНӘГАТЬСЕЗЛӘНҮ *ф.* Канәгатьсезлек туу, ризасызлану. | *и. мәгъ.* [*Хәбибуллин:*] *Бу чибәр егет, мөгаен, шул өч тракторның кырга чыгып китә алмыйча торуларын белеп килгәндер, тик ул турыда үзе сорамыйча, минем сүз башлавымны көтә булса кирәк! — дип эчке бер канәгатьсезләнү белән уйлана.* Ә. Еники.

КАНӘГАТЬЧЕЛ *с.* Канәгатьләнә торган, канәгать була торган. *Тартар ачкүз булганы өчен ябык була, бүдәнә, киресенчә, канәгатьчел булып, симез була.* Н. Исәнбәт.

КАНӘФЕР I *и. бот.* **1.** Аерча таҗ яфракчыклы, шәмәхә, кызыл, ал, ак чәчәк ата торган үлән үсемлек. *Гөләндәм әби генә „бусы әнҗе чәчәк, бусы канәфер чәчәк, бусы күгәрчен күзе - - -“ дип, чәчәкләрнең барысының да исемнәрен санап чыкты.* Г. Гали.

2. *сөйл. к.* сирень. *Тәрәзә алдында эре-эре яфраклы канәфер агачы үсеп тора.* А. Шамов.

КАНӘФЕР II *и. бот.* Мирт семьялыгыннан, алсу яки ак төстәге вак чәчәкле мәңге яшел тропик агач; бөреләре бик хуш исле һәм майга бай була. || Шул агачның бөреләрен киптереп ясаган аш тәмләткеч. [*Хизбулла*] *кырык тартма белән канәфер, дарчын, бадиян сатып, күз буяп йөри.* К. Нәҗми.

КАНӘФЕРЧӘЛӘР *и. бот.* Аеры таҗ яфракчыклы ике өлешле үсемлекләр семьялыгы.

КАНҖЫГА *и. иск.* Иргә әйбер беркетергә жайлап куелган каеш. *Чәймәгә бирсәң карчыга бир, канҗыгаңны буш итмәс.* Н. Исәнбәт.

КАОЛИН *и.* Фарфор-фаянс, кәгазь һ. б. җитештерүдә кулланыла торган утка чыдамлы үзле ак балчык. *Каолин савытлар.*

КАП I *и.* **1.** Гадәттә калын кәгазьдән, чыптадан ясалган зур капчык. *Комбиазыкларны кәгазь капларга салалар.* А. Расих. *Аның әнкәсе кышларын морзалар өчен җеп әрләп, ындырга чыгып, кап сугып гомер үткәрсә, җәйләрен башы урактан кайтмады.* Г. Галиев. || Кәгазьдән ясалган кечкенә пакет. *Кызы берничә лимон белән бер кап шоколад конфетлар китергән икән.* Ә. Еники.

2. *сир.* Футляр, тышча. [*Кызылармеец*] *чибәр несессерның күн кабын тотып, уйланып утыра.* Ш. Усманов. || Конверт. *Хат кабын ертып, күземне язу юлларына төшердем.* Ә. Айдар.

3. *иск.* Тире. *Күреклегә куян кабы да килешә.* Мәкаль.

◇ **Кап булу** — кап кебек зур булу. — *Ну бер сыйлый идем үзегезне! Бүксәләрегез кап булганчы аша-та идем.* А. Гыйләҗев. **Кап корсак** — зур корсак. [*Перико:*] *Әй кап корсак, салам сыйрак, тимә аңа!* А. Әхмәт.

КАП II *и.* Тартма (шырпы, кнопка һ. б. салу өчен). [*Шәриф*] *бер кап шырпы, өч мыскал чәй алып кайтты.* М. Гафури. *Ул пальто кесәсеннән ниндидер зур каплы папирос чыгарды.* Н. Фәттах.

КАП III *кис.* Нәкъ, төп-төгәл. *Карбыз кебек кап урталай ярыр идем дә бу җир шарын, Ике ярым шарны бер-берсенә бәреп, Кояр идем бөтен чүп-чарын.* Ф. Кәрим. *Ульба суын ярып кап уртага, Җимерелмәслек кыршау суктылар.* Ә. Ерикәй.

КАПЕ'ЛЛА *и. муз.* Җырчылар хоры, шулай ук җырчылардан һәм төрле инструментларда уйнаучы артистлардан торган катнаш ансамбль. *Башта аз саннлы, бер тавышлы коллектив хәзер чын капеллага әверелде.* Сов. әд. *Төрле музыка коралларында яхшы гына уйный белүчеләр унике кеше. Болардан музыкаль капелла төзергә.* Ш. Маннур.

КАПЕЛЬ *и. махс.* Сөяк көленнән пресслап ясалган калын чашка.

КАПЕЛЬДИ'НЕР *и. иск.* Театрда билет тикшереп, тәртип күзәтеп торучы.

КАПЕЛЬМЕ'ЙСТЕР *и. муз. иск. к.* дирижер. *Капельмейстерның кулындагы таякка күзләремне төбәп карыйм.* Ф. Әмирхан. || Хәрби оркестр дирижеры.

КАПИЛЛЯР *и.* **1.** *физ.* Бик нечкә каналлы көпшә. || Һәртөрле шундый нечкә канал (мәсәлән, үсемлек, агач күзәнәкләрендә).

2. *биол.* Иң нечкә кан тамыры. *Артерия һәм веналарны иң вак кан тамырлары — капиллярлар челтәре тоташтыра.* Ф. Мостафин.

КАПИТАЛ *и.* **1.** *экон.* Яллы эшчеләрне эксплуатацияләү юлы белән хосусый милек иясенә доход китерә торган кыйммәт. *Даими капитал. Үзгәрмә капитал.* □ *Буржуазия үзенең капиталын, җир-суын саклар өчен ниләр генә эшләмәсен, ахыр барып без җиңәчәкбез!* Г. Ибраһимов. *Сугыш елларында капиталы бермә-бер үскән фабрикант өчен хәзерге хәлләр [революция] чынлап та ут йоттырырлык иде.* К. Нәҗми. || Капиталистлар, сыйныф буларак буржуазия; капитализм. *Без биш елга план төзегәндә, Хыял дип көлсә капитал, Ә гигантлар гөрләп эш башлагач, Җавап барде нефть һәм металл.* Ф. Кәрим. [*Речь сөйләүче:*] *Мәгәр Советлар власте гына җир йөзенең эшчәннәрен берләштереп, - - - изелгән эшчеләрне капитал тырнагыннан, империалистлар коллыгыннан азат итәчәк!* М. Гафури.

2. *сөйл.* Акча байлыгы; байлык. *Дәүләтьяров Маликны шәһәрдә магазин ачып, олы сәүдәгә тотынырга өнди иде.*[*Малик:*] — *Аның өчен капитал кирәк, ә минем...* И. Гази.

КАПИТАЛИЗМ *и. эк.* Яллы хезмәтне эксплуатацияләүгә нигезләнгән иҗтимагый строй, анда барлык төр җитештерү средстволары капиталистларның хосусый милке булып тора; буржуаз строй. [*Салахиев:*] *Ипташлар, диде, талашырга ярамый, диде, хәзер капитализм юк, һәммә нәрсә үзебезнеке.* Г. Ибраһимов.

КАПИТАЛИСТ *и.* Капиталистик җәмгыятьнең хакимлек итүче сыйныф вәкиле: капитал хуҗасы, ялланган эшчеләрне эксплуатацияләүче. *Безгә тик капиталистлар интересы өчен генә башланган бу канлы сугышның тизрәк бетүе кирәк.* М. Гали. *Эш сәгатен кимету көбек мөһим мәсьәләләр буенча капиталистлар белән көрәш бара.* Т. Гыйззәт.

КАПИТАЛИ'СТИК *с.* **1.** Капитализмга мөнәсәбәтле, капитализмга хас. *Капиталистик әхлак.*

2. Капитализм принципларына нигезләнгән. *Капиталистик җәмгыять. Капиталистик эксплуатация.* □ *Хезмәт ияләрен аяусыз изүгә — эксплуатациягә нигезләнгән капиталистик система эшчеләр һәм ярлылар сыйныфыннан исәпсез күп корбаннар чыгарып ташлый.* М. Җәлил.

КАПИТАЛЛАШТЫРУ *ф. махс.* **1.** Капиталга әйләндерү, капитал итү (өстәмә кыйммәтне).

2. Гамәлдәге учет процентыннан һәм килгән табыштан чыгып мөлкәтнең кыйммәтен билгеләү.

КАПИТАЛЛАШУ *ф. махс.* Капиталга әйләнү (өстәмә кыйммәт турында).

КАПИТАЛЬ *с.* Күләме яки әһәмияте буенча зур, мөһим. *Театрның гомуми эш методына карата төп әйтә торган сүз: - - - капиталь әйберләрне куюга күчәргә, сәхнәдә җанлы образлар тудырырга кирәк.* М. Җәлил.

Капиталь ремонт — тулы ремонт (бина, машина, станок һ. б. ларга). **Капиталь стена** — бина һәм корылмада түбә япканда терәк булып хезмәт итә торган төп стена. **Капиталь төзелеш** — халык хуҗалыгының төп фондларын киңәйтүне тәэмин итә торган промышленность һәм торак йортлар төзелеше.

КАПИТАН *и.* **1.** Армиядә өлкән лейтенанттан югары офицер дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәгә ия кеше. *Газинур капитан Бушуев землянкасына килеп кергәндә, рота командиры нәрсәдер укып утыра иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Судно башлыгы, командиры. *Иң соңгылар булып корабтан Отто белән капитан төшәләр, шул вакытта ук боздагыларга булышырга керешәләр.* А. Алиш.

3. Команда җитәкчесе (спортта). — *Безнең заводның теге елдагы шикелле үк [футбол] командасы булырга тиеш! Капитаны да, тренеры да үзең булырсың.* Э. Касыймов.

Капитан күперчеге — корабльләрдә югары палуба өстендә күзәтү алып бару, командалык итү өчен хезмәт итә торган урын. *Кәрим Капкаев бер генә минутка да үзенең капитан күперчегеннән китмәде.* Х. Садрый.

КАПИТАНЛЫК *и.* Капитан вазифасы, хезмәте. [*Рәхим:*] *Нигә спорт командасы капитанлыгыннан алдылар үзеңне!* Г. Әпсәләмов. [*Фадеев*] *„Потехин" пароходын сатып алды да, үзе капитанлык итеп, төнчеге Сашаны лоцманлыкка өйрәтте.* Г. Минский.

КАПИТЕЛЬ *и. махс.* Колоннаның яки пилястрның түшәм белән тоташкан фигуралы өске өлеше. *Театрның көньяк мәйданчыгындагы фонтан һәм, ниһаять, колонна капительләре һәм барельефларның нәфис,*

тасвирлы бизәкләрә бинага мәһабәт төс биреп тоталар. Каз. утл.

КАПИТУЛЯНТ *и.* Авырлыкларга каршы көрәш алып барудан хыянәтчел рәвештә баш тартучы.

КАПИТУЛЯ'НТЛЫК *и.* Капитулянт булу, көрәш алып барудан хыянәтчеләрчә баш тарту. *Ленин* [*V нче*] *съездда меньшевикларның - - - капитулянтлык тактикасын фаш итте.* КПСС тарихы.

КАПИТУЛЯНТЧЫЛ *с.* Капитулянтка хас булган.

КАПИТУЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. *хәрби.* Җиңгән якның куйган шартларына риза булып, сугыш хәрәкәтләрен туктату, корал ташлау. *Менә ничәнче тапкыр инде* [*Левитан*] *Гитлер Германиясенең капитуляция шартларына кул куюын тапшыра иде.* Ә. Еники.

2. *күч.* Үзеңнең җиңелүеңне, хаксызлыгыңны тану, чигенү. *„Капитуляция, чигенү дип уйламасалар ярый инде“, — дип сыкранып хәтерләде* [*Ифрат*] *үзенең Халиков белән талашуын.* А. Расих.

3. *иск.* Көнчыгыштагы бәйле илләрнең капиталистик дәүләтләр белән тигез хокуклы булмаган килешүе; аның буенча капиталистик дәүләтләрнең гражданнары бу илләрдә аерым өстенлекләр, льготалар белән файдаланалар.

Капитуляция ясау — җиңүче якның куйган шартларына риза булып бирелү.

КАПИТУЛЯ'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Капитуляция ясарга мәҗбүр булу. *Берлин гарнизоны капитуляцияли.* СССР тарихы.

КАП-ЙОТ *и.* Саран, комсыз кеше. [*Гыйльмүш*] *— Муенын борып ташларга кирәк кап-йотның! — дип кычкырып җибәрде.* Х. Садрый.

КАП-ЙОТЛАНУ *ф.* Саранлану, комсызлану. *Бигрәк кап-йотланасың инде.*

КАП-ЙОТЛЫК *и.* Кап-йот булу, саранлык, комсызлык.

КАПКА *и.* 1. Корылма, стена, койма һ. б. ш. урынларда кереп-чыгып йөрү өчен махсус эшләнгән ачыклык һәм шул кереп-чыгып йөрү урынын ябу өчен тупсалы җайланма. *Шул вакыт завод капкасыннан бик күп кешеләр күренде.* А. Алиш. *Тыштан кул белән басып ачыла торган авыр гына тимер келәле капкадан Габдулла эчкә керде.* Ә. Фәйзи. *Бер көтү малай, тупырдашып, басу капкасына таба йөгерә иде.* И. Гази. || *күч. сөйл.* Хуҗалык. *Капка рәтеннән көтүгә бер сыер яки алты баш сарык яки ике кәҗә җибәргән кешедә иртә, кич берәр тапкыр ашыйбыз.* М. Гали. || *күч. хәрби.* Дошман чолганышын яки киртәләрне үтү өчен тар аралык (тауларда, диңгездә, сугыш кырында һ. б.). *Саперлар алдан ук, тимер чыбыкларны кисеп, „капкалар“ ясаганнар иде, без шул „капкалардан“ йөгереп кереп алга* [*дошман позицияләренә*] *ташландык.* Г. Әпсәләмов.

2. *спорт.* Хоккей, футбол кебек спорт уеннарында туп, шайба яки шарны бәреп кертүдән саклана торган урын. *Юеш туп казанлылар капкасына керде, җәтмә арасына уралып тырпылдавыннан туктады.* А. Гыйләҗев.

◇ **Капка баганалары бертуган** — туган булмаган, чит кешеләр турында.

КАП-КАЙНАР *с. Артык. дәр. к.* кайнар.

КАПКАН *и. диал. к.* капкын.

КАП-КАРА *с. Артык. дәр. к.* кара. *Әнә ферма тирәсендә берсен-берсе куышып, йөгерешеп, җим ашап ап-ак, чуп-чуар, кап-кара тавыклар йөриләр.* А. Әхмәт.

КАП-КАРАҢГЫ *с. Артык. дәр. к.* караңгы. *Күз ачып йомганчы театр кап-караңгы булып калды.* Ф. Әмирхан.

КАП-КАРТ *с. сөйл. Артык. дәр. к.* карт. *Кап-карт көенчә өченче хатынлыкка яшь кенә кыз алудан азрак оялыгыз.* М. Гафури.

КАПКАЧ *и.* 1. Савыт-саба, чиләк кебек нәрсәләрнең өстен каплый, яба торган җайланма, савытның өсте. *Чәйнек капкачы. Самовар капкачы.* □ *Менә Таифә әби күпереп торган сөт эченә сап-сары тары ярмасын салып җибәрә, болгата, казан капкачын ябып куя.* И. Гази. *Чилгенә күрә капкачы.* Әйтем.

2. Төрле нәрсәләрдәге каплавыч, кечкенә ишек. *Тышта җил тавышы сызгыра, улый, тәрәзә капкачларын селкетә.* М. Фәйзи. *Мич капкачы яңадан ачылды.* Г. Бәширов.

КАПКАЧЫ *и. спорт.* Футбол, хоккей уеннарында капка алдында сакта торган уенчы. *Тупны капкачыга юнәлтү.* □ *Туп сызгырып үтеп киткәч, капкачы да сикергән булды.* А. Гыйләҗев.

КАПКЫН *и.* 1. Кошлар һәм җәнлекләр тоту өчен пружинадан һәм ике тимер дугадан гыйбарәт булган ау җайланмасы. *Иртәгесен Гата, чыгып капкының караса, шакката, авызын ачып көзән ята.* А. Алиш.

2. *күч.* Кемне дә булса кулга төшерү, әләктерү максаты белән оештырылган хәйлә. — *Кешеләрен белеп алгач, аларны капкынга әләктерү бернәрсә түгел.* Ш. Камал. [*Илсөяр*] *бераз хәл алгач, бабасына һәм яңа дусларына кызылкүзнең оста корылган капкыны турында сөйләде.* Г. Гобәй.

◇ **Капкын кору** — хәйлә кору, хәйләләү. **Капкынга төшү (эләгү)** — 1) нинди дә булса бер эштә эләгү, тотылу. *Авыл халкының бер өлеше* [*„главный комиссардан“*] *закон бозучы начальникларны капкынга әләктерүен көтте.* К. Нәҗми; 2) берәр нинди максаттан чыгып корылган хәйләне сизмичә берәрсенең кулына эләгү, бәйле хәлгә төшү. [*Закир Гайни турында*] *— Хәзер капкынга төштең инде! Бик тиз миннән котыла алмассың!* Г. Камал.

КАПЛАВЫЧ *и.* 1. Нәрсәне дә булса өске яктан каплап тора торган җайланма, капкач. [*Пароходта*] *тәгәрмәч каплавычының уентыларыннан каксыган кисмәк исен бөркеп торучы җылымса бу аркылы* [*кешеләрнең*] *йөзләрен дә, кием-салымнарын да шәйләп булмый.* К. Нәҗми. *Өй эченә керүгә - - - каплавычлы тегү машинасын, идәндәге яңа чемоданнарны күреп тагын уйга каласың.* Г. Галиев.

2. Дошман игътибарын үзләренә җәлеп итеп, төп көчләрнең китүенә яки нинди дә булса операцияне башкарып чыгуына ярдәм итү өчен махсус билгеләнгән отряд яки кешеләр. *Өченче рота, каплавыч булып, урман кырыена ята һәм төп көчләргә юл алырга мөмкинлек бирә.* Ш. Маннур.

КАПЛАМ *и.* 1. Нәрсәне дә булса каплап алган тышкы катлам. *Кар капламының калынлыгын кар үлчәгеч рейка ярдәмендә үлчиләр.* Физ. геогр.

2. Организмны тулысынча яки өлешчә генә каплаган тышча, катлау. *Йон капламы.*

КАПЛАМА *и.* 1. Күлмәк һ. б. ш. ларда сәдәф һәм әләктергечләр урнашкан планка. *Ни өчен, мәсәлән,* [*костюмда*] *капламаларны аерым алып эшләргә, ни өчен аларны кисү өчен шул ук тегү машинасына җайланма куймаска.* Соц. Тат.

2. *диал.* Бал, май һ. б. лар салу өчен капкачлы кечкенә савыт. *Бер каплама май, бавырсак.* Т. Гыйзәт.

КАПЛАМЫШ *и. диал. к.* каплама 2. *Көз көне Рәхмәтулла карт аркылы Гөлйөзем карчыктан аңа - - - бер капламыш савыт белән яңа гына умартадан алган бал я корт-фәлән килә.* М. Гали. *Дүрт-биш каз алсаң, бер капламыш шомыртлы сары май - - - бик әйбәт булыр, — диде* [*Гафифә*]. Г. Галиев.

КАПЛАН *и. зоол.* Мәчесыманнар семьялыгыннан кара таплар төшкән сары тиреле эре ерткыч хайван. *Каплан тиресен җәйдек тупсага.* М. Җәлил.

КАПЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* каплау.

2. Төбе, аскы ягы белән өскә әйләнү; асты өскә әйләнү. *Илсөяр бабасына булышырга тели, ләкин койрыкны ычкындыруга көймәнең капланууыннан куркып бу фикерәннән кире кайта.* Г. Гобәй.

3. Йөз белән нәрсәгә дә булса яту, йөзне каплау. *Гөлзадә кинәт пианино клавишларына каплана.* Р. Ишморат. [*Газизә*] *бераз торганнан соң өйгә керде һәм мендәренә капланып әкрен генә үксеп-үксеп елый башлады.* Ш. Камал.

4. Йөзтүбән егылу, йөзтүбән авып төшү. *Мөнирә атып җибәрде. Төтен таралганда фин йөзтүбән капланган иде.* Г. Әпсәләмов.

5. *күч.* Барлык игътибарны берәр нәрсәгә юнәлтү, берәр нәрсә белән бик нык мавыгу. *Иртәдән кичкә кадәр китапка капланып утыру.* □ *Әгәр дә язга табарак булса, шәһәр халкы ачы-төче нәрсәгә бигрәк тә капланып төшә инде.* М. Шабай.

КАПЛАТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* каплау.

2. Малларны кушылдыру, йөгертү. *Таналарны соңга калып каплату көтүнең үрчүен тоткарлый.* Сөт терлекчелеге.

КАПЛАУ *ф.* **1.** Берәр нәрсәнең өстенә, түбәсенә икенче бер нәрсәне түшәү, җәю. *Әүхәдигә әйтегез: иртәгә үк йорт түбәсен капласын.* Һ. Такташ. || Берәр әйбернең өстен капкач белән томалау, ябу. [*Сәгыйдә карчык*] *самоварны каплый-каплый: — Балакай, тарсынмый гына аша, эчегез, — диде.* Ш. Камал.

2. Бер әйберне икенче бер әйбер белән бөркәү. [*Рәүфә*], *тиресе уелып чыккан кулын алъяпкычы белән каплап тотып, тәрәзәгә таба борылды.* А. Шамов.

3. Ике предмет арасына туры килеп, аларның бер-берсенә күренерлек булуына комачаулау. *Ул арада Москва поезды,* [*Гәрәйләрнең*] *составын каплап, ни өчендер йөрешен акрынайтып, салмак кына узып китте.* К. Нәҗми.

4. Кереп-чыгып йөрү, үтү юлын бикләү, ябу. *Ишектәге авыр, калын йозак Юлын каплап тора бит аның...* Ф. Кәрим.

5. Тәрәзә, ишек һ. б. ларны берәр нәрсә белән ябу, томалау. [*Ризван:*] *— Тәрәзәләрне палас белән капларбыз да мыштым гына утырырбыз.* Т. Гыйззәт. *Тәрәзәләрнә фанера өлгеләр белән капладылар.* А. Расих.

6. Берәр нәрсәнең астын өскә әйләндерү. *Багана төбенә зур кисмәк каплап куелган.* Г. Гобәй. *Кунаклар исә әүвәлге чынаякны эчкә тә чынаякларын каплап куйдылар.* Ф. Әмирхан. || *күч.* Суны, эчемлекне төбенә кадәр эчү, бушату. *Уразбикә, мич почмагына сөялеп, бер тында стаканны каплады да ишеккә таба барды.* Г. Ибраһимов. *— Гитлерны җиңеп кайту өчен булсын, - - - дип чокырны капладым да җырлап җибәрдем.* Ә. Айдар.

7. Томалау (болыт, томан, караңгылык, күз яше һ. б. лар турында). *Иделне төтен каплаган.* Ә. Еникәй. *Аннан соң җир өстен аксыл томан каплап ала.* Ә. Айдар. *Тау кырыена утырган Ташлыяр авылын - - - зәңгәр төтен каплаган.* А. Алиш.

8. *күч.* Киң мәйданга, пространствога, өлкәгә таралу, җәелү турында (тавыш, куркыныч хәл, дәһшәт, кризис һ. б.). *Кинәт бөтен урман эчен дәһшәтле гөрселдәү каплап алды.* Ә. Еники.

9. Басу, күмеп китү (үлән, кар, тузан һ. б. ларның берәр нәрсәне). *Тугайлыкны каплаган куе яшеллек эчендә санап бетергесез төрдәге кошлар бергә кушылып сайрыйлар.* М. Әмир. *Җир өстен ап-ак кар каплаган.* Г. Гобәй. || Башка күренештән көчлерәк булып, аның тәэсирен югалту, басу. *Һәммә нәрсәне каплап, моржалар арасында сызгырып уйнаган каты буран эчендә ялгышып башка тәрәзгә бара күрмәсен* [*Лотфи*] *дип тә тынычсызланды* [*Гөлбану*]. Г. Ибраһимов. || Бик күп булу, күпләп чыгу (җыерчык, сипкел һ. б. лар). *Мин - - -* [*карчыкның*] *җыерчыклар каплаган кайгылы йөзеннән үбеп саубуллаштым да катерга таба киттем.* Г. Минский. *Бозлы баткак, ботинка ертыкларыннан табанга, тубыкка сыланып, бөтен гәүдәне каз тәне каплый...* К. Нәҗми.

10. *күч.* Тотылган расходларны кайтару. [*Җитмәүчелекнең*] *калган кадәресен шунда ук акча кертеп капладылар.* Ә. Еники. *Вак заказлар гына бу зур заводларның чыгымын каплый алмый башладылар.* Ә. Фәйзи.

11. *күч.* Җитешсезлекләрне, начар эшләрне яшерү, күрсәтмәү. *Безнең кайбер язучыларыбыз үзләрендәге идея түбәнлеген яки идеясезлекне „матур форма", „матур сүзләр" белән капларга тырышалар.* Һ. Такташ. *Мин дә ялкау ягын якламыймын, Гөнаһлының гөнаһларын капламыймын.* З. Мансур. || Булган сәләт яки алга омтылышны басып, томалап тору. [*Иштуган:*] *Ник, мин әйтәм, мондый кыйммәтле тәҗрибәңне каплап яттың?* Г. Әпсәләмов.

12. *күч.* Үз тәэсиренә дучар итү (кайгы-хәсрәт, күңелсезлек һ. б. лар). *Без кайтып кергәндә, өйнең эчен кайгы-хәсрәт каплап өлгергән иде.* М. Гафури. *Соңыннан күңелне әллә нинди бер бушлык, бер эч пошу каплап ала иде.* Ф. Әмирхан.

13. *хәрби.* Махсус билгеләнгән отряд яки сугышчыларның, дошман игътибарын үзләренә җәлеп итеп, төп көчләрнең чигенүенә яки нинди дә булса операцияне башкарып чыгуына ярдәм итүе. □ *Чыккан чакта үз часте елганы, Каплап тору өчен уттан аны, Ни булса да үзем күрим, дип, бер түмгәккә посты Спринг.* Ә. Исхак. *Газинур Володяның соңгы группа белән безнекеләрнең чигенүен капларга калганлыгы турында әле бүгенгәчә* [*Екатерина Павловнага*] *әйткәне юк.* Г. Әпсәләмов.

КАПЛАУЛЫ *с.* Өсте ябылган, капланган. *Аның йөзе ак сөлге белән каплаулы.* Г. Ибраһимов. *Каплаулы казан каплаулы калсын.* Мәкаль. || Тышланган. *Калай белән каплаулы өстәл.* Ф. Әмирхан.

КАПЛУН *и. а-х.* Иткә симертү максаты белән печтерелгән этәч.

КАПМА-КАРШЫ *с.* **1.** Бер-берсенә туры килмәгән, охшамаган; бер-берсен инкяр итә торган, бөтенләй киресенчә булган. *Нәгыйбнең җавабы* [*комсомолецларныкына*] *капма-каршы иде.* Ш. Камал. || Каршылыклы. [*Нуруллинның*] *күңелендә гаҗәп капма-каршы уйлар йөри иде.* А. Шамов.

2. *рәв.* Кара-каршы, йөзгә-йөз. [*Малайлар*], *көзге әтәч шикелле, бер-берсенә капма-каршы килеп басканнар.* А. Әхмәт. [*Зыя*] *калын тышлы бер китап алды да, айга капма-каршы булган бер тәрәзәнең янына утырып, күктән килгән яктылыкта яза башлады.* Г. Ибраһимов.

КАПОНИР *и. хәрби.* **1.** Капма-каршы юнәлештә ут ачарга мөмкинлек бирә торган оборона корылмасы.

2. Самолетларны яшерү урыны. *Тагын күбрәк юл үтәсе, сугышны тизрәк бетерәсе килә. Командир да, шул теләкне аңлаган кебек, безнең сафны капонирлар өстеннән үткәрә.* С. Баттал.

КА'ПОР *и.* Хатын-кызларның һәм балаларның, битне генә ачык калдырып, яктан астыннан тасма белән бәйләп кия торган баш киеме.

КАПОТ *и.* **1.** *иск.* Хатын-кызларның киң итеп тегелгән, өйдә кия торган күлмәге. [*Ишектән*] *иске*

генә йон капот кигән, ак чәчен өскә өйгән бер хатын күренде. Г. Газиз.

2. *техн.* Төрле механизмнарда аларны тузаннан, юештән һ. б. лардан саклый торган ачылмалы тимер капкач. *Шофер капот капкачын ачты да башы белән эчкә таба сузылды.* Г. Ахунов.

КАПОТАЖ *и. махс.* Авариянең бер төре: җиргә төшкәндә яки күтәрелгәндә самолетның баш аркылы әйләнүе.

КАПРАЛ *и. иск.* Кайбер илләрдә һәм XVII йөздән XIX йөзгә кадәр рус армиясендә: кече командир исеме, һәм шул исемгә ия булган кеше. [*Гөлниса:*] *Улым, бу солдат киемнәреңне салсаң да ярар иде. Бердән, үзеңә эссе, икенчедән, унбиш көннән бирле капрал солдат булып йөрүеңне яратмыйм.* Т. Гыйззәт.

КАПРИЗ *и.* **1.** Урынсыз теләк; кинәт барлыкка килгән көйсезлек, кирелек. *Марзиягә аерым бүлмә кирәк булды. Бу — Марзиянең иркен яшәргә теләүдән килеп туган капризы түгел.* Г. Ахунов. *Бала капризына буйсынуның да чиге бар бит.* Б. Камалов.

2. *күч.* Нинди дә булса көтелмәгән, очраклы хәл. *Җир белән табигать капризын - - - буйсындыру җиңел эш түгел.* Р. Ишморат.

КАПРИЗЛАНУ *ф.* Иркәләнеп көйсезләнү, киреләнү, холыксызлану. *Артыкбикәнең килеп чыгуы, капризланып чыгып киткән Зояга караганда яхшы уйнавы - - - безне чиктән тыш бәхетле итте.* М. Әмир.

КАПРИЗЛЫ *с.* Көйсез, холыксыз, урынсыз назлы. *Аннары без, авырулар — бик капризлы халык.* А. Шамов. [*Соня*] *капризлы кызлар тавышы белән әйтте: — Минем үлеп-үлеп арыйсым килә.* И. Гази.

КАПРОН *и.* **1.** Ясалма сүснең бер төре.

2. Шул сүстән ясалган тукыма. || *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Безнең алда чем-кара өфәк халат эченнән җете ак капрон кофта якасын чыгарып кигән яшь кенә хатын тора иде.* Каз. утл. [*Сәгыйть Иданың*] *тән төсендәге капрон оек кысып торган тулы, матур балтырларын - - - күрде.* Н. Фәттах.

КАПРОНЛЫ *с.* Капрон (1 мәгъ.) катнашкан, капроны булган. *Лавсанлы, капронлы һәм башка синтетик җепле тукымалар да дымлы чүпрәк аркылы җылымса үтүк белән үтүкләнә.* Соц. Тат.

КА'ПСУЛ *и. сөйл. к.* капсула. [*Мөгълифә:*] *Бөрәр капсул хин кабып җибәрсәң, хәзер* [*башың*] *төзәлеп китәр.* Г. Камал.

КА'ПСУЛА *и. махс.* Бер йотым даруның крахмалдан, желатиннан яки кәгазьдән ясалган, йоткач җиңел эри торган тышчасы.

КА'ПСУЛЬ *и. к. капсюль. Ялгыш тартылып киткән курок ычкынып чакманы капсульгә бәрде.* Г. Гобәй.

КА'ПСЮЛЬ *и.* Патроннар һ. б. ларның зарядын кабызуга ярдәм итүче, бәрүдән шартлап китә торган матдәле металл калпак. [*Водолазлар килгәндә*] *Рәшит шлакка күмелгән дүрт бомбаны аралап чыгарып, капсюльләрен алган иде инде.* К. Дәүләтшин.

КАПТАЖЛАУ *ф.* Язгы сулар һәм чүп-чар кермәсен өчен чишмәләрне тимер-бетон белән буралап, өсләрен томалау. *Шушы арада траншеялар казып трубалар күмү һәм чишмәләрне каптажлау эшләре башланырга тиеш.* М. Хәсәнов.

КАПТЕНА'РМУС *и. иск.* Армиядә: азык-төлек, кием-салым һәм коралларны саклау һәм бирү белән шөгыльләнүче кеше. *Завхоз Сафин, үзенең каптенармусларын иәртеп, җирдә өелеп яткан он, солы капчыкларын, шинель, гимнастерка төбеннәрен, патрон, граната, консерв ящикларын - - - санап, кайсын кая кертергә кирәклеге турында инструкция биреп йөри.* Ш. Усманов.

КАПТЫРГЫЧ *и.* Төрле нәрсәләрне кыстыру, электерү, беркетү өчен хезмәт итә торган җайланма.

КАПТЫР-КОПТЫР *рәв.* Ашык-пошык, тиз-тиз. [*Маһирә*] *каптыр-коптыр атлый-атлый тар ишеккә кереп югалды.* А. Гыйләҗев.

КАПТЫРМА *и.* Кием һ. б. нәрсәләрдә эләктерү, каптыру өчен хезмәт итә торган, бер башка бөгеп эшләнгән җайланма. *Кыз Нуруллинның шинель каптырмаларын ныгытып утырганда, эскадрон командиры да килеп керде.* А. Шамов.

КАПТЫРМАЛАУ *ф.* Каптырмасын эләктерү. [*Батырҗан*] *изүләрен каптырмалады.* Р. Ильяс.

КАПТЫРМАЛЫ *с.* Каптырмасы булган, каптырма белән эләктерелә, ябыла торган. *Нәҗип каптырмалы кыр сумкасыннан берничәсе белән бергә тегелгән дәфтәрләр алды.* Г. Гобәй. [*Солтанның*] *аякларында постау өсле - - - каптырмалы галошлар иде.* А. Расих.

Каптырмалы стан — туку белән вакытлыча гына шөгыльләнгән очракта, киндер станының детальләрен сәке такталарының берничәсен алып, сәке кысасына гына эләктереп җайлана торган стан. *Дининең, урам буе өенең кече ягында, үзе суга торган каптырмалы станы бар.* М. Гали.

КАПТЫРУ I *ф.* **1.** Кабарга бирү. *Имезлек каптыру. Алма каптыру.*

2. Ашарга бирү, бераз гына ашату. [*Атка*] *авылдан алып килгән бәрәңге белән икмәк сыныкларын каптырып алырга туры килде.* Г. Бәширов.

КАПТЫРУ II *ф.* **1.** Эләктерү (сәдәфне, каптырманы һ. б). *Хафиз - - - стенадагы көзгегә карап чәчләрен рәтли, изүләрен каптыра.* Р. Ишморат.

2. *сөйл.* Кармак белән балык тоту. *Өчәүләп балык каптыра башладык.* А. Әхмәт.

3. Чабып кадап кую (балтаны). *Менә ул бер-ике кочак коры-сары ярды да балтасын йөзе белән түмәр башына каптырып куйды.* Г. Галиев.

4. *сөйл. күч.* Эләктерү, ычкынмаслык итеп тоту. [*Имәли*] *халык арасыннан атылып чыкты да озын кулы белән Тәкъва Сәхәүнең иңбашыннан каптырып тотып алды.* М. Әмир. || Алдап кулга төшерү, серен алу. *Николаев һич хәйләсез, мәкерсез күрешү белән* [*Тангатаровны*] *каптырырга уйлады.* Г. Ибраһимов. || Тоту, яшеренеп йөргән кешене эләктерү, кулга алу. *Без каптырдык бу корткычны* [*дивәрсантны*], *Ул бер-бәр хәл иткәнче.* М. Җәлил.

КАПУ *и. иск.* **1.** *к.* капка 1. *Зиндан капусы янында ук бер төнге каравылчы солдат стенага сөялеп гырылдап йоклямакта иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *к.* капкач 2. *Тәрәзәмнең капусына Моңлы кош килеп кунган.* Җыр.

КАПЧЫК *и.* **1.** Коела, чәчелә торган әйберләрне салып саклау һәм бер урыннан икенче урынга ташу өчен, тупас тукымадан яки кәгазьдән бер башы гына ачык калдырылып тегелгән кап. *Гарифның алып китә торган әйберләрен капчыкка тутырып рәтләп куйдылар.* М. Гафури.

2. *сөйл.* Бөртекле әйберләрне үлчәү берәмлеге: 3—5 пот чамасы. *Икенче көнне үк Малик егерме биш капчык бодайны китереп тапшырды.* И. Гази. [*Мөршидә:*] *— Әнә, үзем белән ике капчык азык китердем.* Т. Гыйззәт.

3. Хайваннарда яки үсемлекләрдә аның бер өлешен яки органын үз эченә алган тышча. *Ут капчыгы.* □ *Наратбашның сабак очында споралы капчыклардан торган башакчыклар була.* Ботаника.

4. *хәрби.* Гаскәрнең тулы камалышы. *Дошманның моңа кадәр тынып торган пулеметлары фланглар-*

дан ут ачты. Без гүя ут капчыгына килеп кердек. Г. Әпсәләмов.

◇ **Капчык авызы** *хәрби.* — капчыктан (4 мәгъ.), камалыштан чыгарга мөмкин булган ачыклык. *Артта ике-өч чакрым гына киңлектәге „капчык авызы" калды.* Ш. Маннур. **Капчык төбен селкү** — 1) барлык булган запасны бетерү; 2) серне ачу, сөйләп бетерү. *Абыйсының серен белгән хәйләкәр малай капчыкны төбеннән тотып селекмәде.* І. Әпсәләмов.

КАПЧЫКЛАНУ *ф.* 1. Капчык формасын алу, салыну, киңәеп калу (киемнәр турында). *Рамазан картайган, бөкрәйгән, сюртук чабулары салынган, аркасыннары да бер дә спай түгел — капчыкланып тора.* Ш. Камал.

2. Шешенкеләнү (күз төбе, тамак асты һ. б.). [*Әпипә*] *шушы берничә ай эчендә бик нык таушалган, күз төпләре капчыклана башлаган, битләре дә, иренәре дә сулган.* Г. Бәширов. [*Майпәрвәзнең*] *капчыклана төшкән күз төпләре агарып тора.* Ә. Еники.

КАПЧЫКЛЫ *с.* 1. Капчык тоткан, капчык күтәргән. *Озак та үтмәде, өченче класс залы сөтче хатын-кызлар, бала-чагалар, капчыклы крестьяннар белән тулды.* А. Шамов.

2. Капчыкка тутырылган, капчыкка салынган. *Кунаклар һәммәсе үзләре китергән капчыклы нәрсәләрне бушатырга тотыналар.* Ф. Әмирхан.

КАПЧЫКЛЫК *с.* 1. Капчык тегә торган, капчык тегәргә яраклы. *Капчыклык тукыма.*

2. Бер капчык тегәргә җитәрлек.

КАПЧЫКЧЫ *и. иск. сөйл. к.* спекулянт. *Эшчеләрне кочкан Автобуслар Капчыкчыны үртәп узалар, Күрәсеңме: берсе муенын бөккән, Аркасында өч-дүрт урындык.* М. Крыйм0в.

КАПШАВЫЧ *и.* Күп кенә кортларның, моллюск, буынтыгаяклыларның, кайбер җәнлек-җанварларның сизү, эләктерү, ә кайбер вакытта сулыш органы да булып хезмәт итә торган авыз янындагы хәрәкәтчел үсенте. *Сигезаякның өзгәләнгән капшавычлары палуба буйлап сөйрәлеп барды.* Каз. утл.

КАПШАНУ *ф.* Кармалану, эзләнү. *Таныш кеше түгеллеге капшанып, ишек бавын таба алмыйча азаплануыннан ук сизелеп тора иде.* М. Хәсәнов. *Якуб целде дә, капшанып, үлән арасыннан ике алма табып алды.* И. Гази.

КАПШАУ *ф.* 1. Кул белән эзләү, кармалау. *Дәүли җиргә целеп үләнне капшый һәм шунда ук төчкереп җибәрә.* А. Әхмәт. *Степаныч бер сыңар күн итеген салды һәм чалбар балагын капшап карады.* А. Шамов.

2. Берәр нәрсәнең урының табу, билгеләү өчен пулемет уты, ут көлтәсе яки берәр прибор белән эзләү, тикшерү. *Менә яссы борынлы броневиклар, тирә-якны капшап, пулеметларын төзәгән килеш урыннарыннан кузгалдылар.* К. Нәҗми. [*Хәлим*] *фонарь яктысы белән мунчаның һәр җирен капшап чыкты.* Г. Гобәй.

3. *күч.* Җентекләп карау, дикъкать белән күзәтү. [*Газинурның*] *күзләре, һәр урне, чокырны капшый-капшый, прожектор нуры шикелле, яңадан яктан-якка йөри башлый.* Г. Әпсәләмов. [*Сәйфинең*] *уң күзе чекерәеп торса да, сулы юри шулай йомылган булып, җыен тешсез урыннарны капшый кебек.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Нәрсәне дә булса белергә, эзенә төшәргә, табарга тырышып төпченү. *Бер-беребезнең чамасын тарттык, йомшак якларны капшадык.* Ф. Хөсни.

КАПЫЛ *рәв.* 1. Кинәт, бик тиз. — *Әйдәгез, дуслар, тизрәк шылыйк моннан, — дип, капыл кабалана башлады.* С. Сабиров. || Көтмәгәндә, искәрмәстән. *Кешеләр капыл гына - - - йөгерешә башладылар.* М. Гафури.

2. *с. мәгъ. сөйл.* Кабынып китүчән, холыксыз, тотрыксыз. *Капыл кеше.*

КАПЫЛ-КОПЫЛ *рәв.* Ашык-пошык, аннан-моннан. *Хәлимнәр сугыш-сугыш уйныйлар. Алар дәресләр бетүгә капыл-копыл ашап чыгалар да - - - ике авыл уртасындагы тауга таба китәләр.* Г. Гобәй.

КАПЫЛЛЫК *и.* 1. Кинәтлек, тизлек. *Карпов килгән көнне - - - капыл балкып янып киткән лампочкалар, гадәттәгечә, шундый ук капыллык белән сүнеп тә киттеләр.* М. Әмир.

2. Кабынып китүчән, капыл кеше булу.

КАПЫЛТ *рәв. к.* капыл. [*Кемнәрдер*] *чаршау почмакларын зур итеп ачып капылт ябалар.* М. Фәйзи. *Мәдинә капылт кына җавап кайтара алмады.* М. Хәсәнов. | *с. мәгъ. Укытучылары да, ипташларе дә мондый капылт эшкә хәйран калдылар.* А. Расих.

КАПЫЛТЛЫК *и. к.* капыллык 2. *Жаденко сак кына уйлана иде, яшь журналистның капылтлыгы - - - бер тамчы ошамаса да, ул әлегә аны сиздермәде.* А. Гыйләҗев.

КАПЫРУ *ф. диал.* Бөтенесен кулга төшерү, үзенә алу. — [*Байлар*], *улым, иртүк торганнар да бөтенесен дә капырып алганнар.* И. Гази.

КАР *и.* Болытлардан ява торган кристалл сыман яки төрле формадагы ак төсле атмосфера явым-төшеме. *Кар көрәү. Кар бураны.* □ *Кара җир өстен ак бөртекләр белән чуарлап, эре, йомшак кар ява башлады.* А. Шамов. || Шул явым-төшемнең пространстволы каплап алган тоташ массасы. *Юлларыбызны кар күмеп китә, җимеш бакчаларыбызны суык кимерә.* Р. Ишморат. *Бөтен җир ап-ак карга күмелде.* Г. Әпсәләмов.

Кар бабай — *к.* кыш бабай. **Кар базы** — боз яки кар салып калдырыла торган баз. *Кар базыннан чыккан салкын карлыган вареньесы белән ике самовар чәй эчтеләр.* А. Гыйләҗев. **Кар китү** — яз көне кар эрү. [*Тәзкирә:*] — *Кар киткәч тә, җирне агуларга туры киләчәк.* Г. Гобәй. **Кар тоту** — ясалма каршылыклар тудырып, ачык кырда кар туплау. *Бөтенебез кырда кар тоттык.* Ә. Ерикәй. **Кар чәчәге** *бот.* — *к.* умырзая. *Кар чәчәгенә кунып утырган сары күбәләк очып китә.* Х. Госман.

◇ **Кар астында калу** — онытылу.

КАР *авазияр.* Карга кычкырган тавышны белдерә торган сүз. [*Карганың*] *кап-кара канатлы кап-кара балалары карама ботагына кунаклаган килеш: — Кар! Кар! — дип кычкырып тораллар икән.* А. Алиш.

КАРА І *с.* 1. Корым, күмер төсендәге; *киресе:* ак. *Кара күлмәк. Кара чәч.* □ *Нәчкә булып сузылып киткән кара кашлар астыннан тыныч, рәхәт итеп карый торган чем-кара күзләр күксел тауларга йөтылганнар.* М. Әмир. *Сабир абзый җәһәт кенә чөйдән кара тунын алып кия башлады.* Ә. Еники.

2. Гадәттәге яки төп төскә караганда куерак төстәге, караңгырак төстәге. [*Сәләхинең*] *маңгаена кара кан оешып каткан, йөзе киндер төсле ак.* Ш. Камал. *Туктаусыз кара болытлар күчеп йөри торган шомлы төн.* А. Әхмәт.

3. Караңгы, яктылык төшми торган, куе (урман турында). *Кара урманга кергән чакта, Кисеп алдым пар каен.* Җыр.

4. Кояш яндырудан аклыгын югалткан яки гомумән ак булмаган (кешедә бит, тән төсе турында). *Аннары Хәлим кара малай белән куышып йөрде.* И. Гази. *Елгыр кара кыз: „Карап керим әле", — дип, әкрен генә шылды.* Г. Ибраһимов. || Раса билгесе буларак, ак тәнлеләргә капма-каршы булган караңгы төстәге. *Скоттсборо шәһәре урамында һәр ишектә шундый язу бар: „Монда этләр белән кара тәнлеләрне — негрларны керту ярамый!"* Ф. Кәрим.

5. *и. мәгъ.* Кара төстәге ат турында. *Ләкин зур кара [ат] мондыйны күп күргән, хуҗасыз арбаларны күп ташыган иде.* Г. Ибраһимов.

6. *и. мәгъ. күпл.* **каралар.** Шахмат, шашкада акка капма-каршы як фигуралар. *Каралар белән уйнаган Бронштейн беренче 15 йөрешкә ике сәгать вакыт тотты.* Соц. Тат.

7. Керле, пычрак, юылмаган. [*Сәгыйдә*] *корзиннан идәнгә кара керләр алып ташлый.* Һ. Такташ. [*Кеше*] *көймә утыргычындагы кабымлыкларны кара бармаклары белән әвеш-түеш китерә.* Г. Бәширов.

8. Квалификациясез, аерым осталык сорамый торган (авыр, пычрак, гадәттә физик эшкә карата кулланыла). *Зәйнәп эшли кара эш, уку-язу белмәгәч.* М. Гафури. *Бу килен сүзсез, талашсыз булып чыкты, кара эшкә гажәп батыр.* Г. Ибраһимов. || *иск.* Шундый эшләрне башкара торган (кеше). [*М. Гафури*] *итчеләрдә хезмәтче булып эшләүдән башлап Рәмиевләрнең алтын приискаларында кара эшче булып эшләүләрне дә башыннан кичерә.* М. Җәлил.

9. *иск.* Революциягә кадәр: гади халык арасыннан чыккан, укымаган, надан. [*Ханзафа:*] *дәттем мин сиңа, кара мужик кызына өйләнмә дидем, тыңламадың.* Т. Гыйззәт. [*Шәмгун:*] *Без язу-сызу белән эш иткән халык түгел. Кара халык.* А. Шамов. || *күч.* Культурасыз, надан, артта калган. [*Баязитны*] *Каргалының биш йөз шәкертле, кара, кадим, фанатик мәдрәсәсенә салалар.* Г. Ибраһимов.

10. *күч.* Фаҗигале, шатлыксыз, авыр (тормыш, көннәр һ. б.). *Илсөярнең күз алдыннан әнисенең кара язмышы тезелеп үтте.* Г. Гобәй. *Искән җил белән, аккан суны кире кайтарып булмаган кебек, үткән кара көннәр шәүләсен искә төшерүдән дә файда юк.* Т. Гыйззәт.

11. *күч.* Бик көчле. *Кара кайгы. Кара явым.*

12. *күч.* Явыз, мәкерле, җинаятьчел. *Давыл үтте, явыз фашистларның Кара ниятләрен сүндереп.* Э. Ерикәй. *Тик белә ул* [*сакчы:*] *Дошман кара эшен эшли күбрәк шундый төннәрдә.* Ә. Исхак.

Кара балык *зоол.* — карп балыклары семьялыгына керә торган, бик вак тәнкәле кара төстәге балык; *русчасы:* линь. [*Карт:*] *Мурдаларны теге камышлыкның уң ягына, тирәнгә салдым. Кара балык эләгеп куймасын.* М. Хәсәнов. **Кара бөрлегән** *бот.* — 1) сабагы чәнечкеле, үрмәләп үсә торган үсемлек; 2) шуның кура җиләгенә охшаш каралҗым шәмәхә төстәге җиләге; *русчасы:* ежевика. *Кара бөрлегән җыйганы да исендә* [*Зәһидның*] *- - - пешеп өлгергәне аның шәмәхә кара төстә, өстенә күгелҗем ак көл сибелгән кебек.* А. Расих. **Кара груһ** *тар.* — *к.* карагруһ. **Кара елан** *зоол.* — 1) агулы елан; 2) *күч.* эчкерле, мәкерле кеше турында. — *Эче тулы кара елан икән.* М. Фәйзи. **Кара зирек** *бот.* — каен агачлары семьялыгына керә торган, күбесенчә елга, күл буйларында урман булып үсә торган агач. **Кара кан** *анат.* — веналардагы кан. **Кара карга** *зоол.* — кара ялтыравык каурый белән капланган, каргалар семьялыгына керә торган кош. **Кара карлыган** *бот.* — *к.* карлыган. *Якында гына тәмле кара карлыган исе, чия яфрагы исе килә.* И. Гази. **Кара кофе** — сөт салмый кайнатылган кофе. *Икенче бер кыз - - - кечкенә генә чәйнек һәм чынаяклар белән кара кофе керттте.* Ш. Маннур. **Кара кымыз** — махсус эшләнә торган исерткеч кымыз. **Кара мунча** — моржасыз мунча. *Аста ярга терәп салынган кара мунчалар тезелеп киткән.* Г. Гобәй. **Кара пар** *а.-х.* — ныгытып эшкәртелеп, бөтен җәйгә чәчелми калдырылган җир. **Кара солы** *бот.* — сабан ашлыклары арасында үсә торган чүп үләне. *Чәчү машинасы артыннан йөргән Сибай карт орлыкның эре бөртекле кара солыдан арчылмавын күрсәтте.* М. Җәлил **Кара су** *мед.* — *к.* глаукома. [*Профессорның*] *күзләренә кара су төште.* А. Расих. **Кара тал** *бот.* — таллар семьялыгына керә торган агач яки куак. **Кара туры** — кара төстәге ат. **Кара шар** *иск.* - берәр төрле дәүләт органына сайлаганда кандидатка каршы салына торган шар. [*Бер байбәтчә*] *- - - шәһәр сайлауларында - - - үзенең кандидатурасын куя, табигый, берничә унлап кара шарга каршы икеме, өчме ак шар алып җиңелә.* Ф. Әмирхан. **Кара өй (як)** *иск.* — хезмәтчеләр тора торган, кышын терлек-туар кертелә торган өй, бүлмә. *Без - - - тәбәнәк түшәмле, җир идәнле кара якны үтеп, - - - икенче бүлмәгә барып кердек. Бу терлек-туар кертелми торган ак як иде.* А. Шамов. *Днисе* [*Габдулланы*], *кара өйгә алып чыгып, үги әтисеннән яшереп сыйлады.* Ә. Фәйзи. **Кара җиләк** *бот.* — 1) дымлы, сазлыклы урманнарда үсә торган бик вак куак үсемлек; 2) шуның зәңгәрсу кара төстәге җиләге; *русчасы:* черника. *Иксез-чиксез сазлыкларда бу айда кара җиләк өлгерә.* Э. Касыймов. **Кара җимеш** — „венгерка“ сортлы киптерелгән слива. *Син хәзергә әнә теге зур савыттан кара җимеш белән йөземне әрчи тор.* Ә. Фәйзи.

◇ **Кара акыл** — нинди дә булса өлкәдә белгеч булмыйча гына, үз исәбе белән генә фикер йөртүдә әйтелә. *Ярты дисәтинәгә бодай белән солыны алтышар пот чәчәргә кирәк булгач, тоткан да кара акыл белән тарыны да шулай иткән* [*Исмәгыйль*]. Г. Толымбай. **Кара алтын** — нефть. *Иксез-чиксез илебезнең төрле тарафларына, җир асты торбалары буйлап, күпме „кара алтын“ — Татарстан нефте ага.* Г. Ахунов. **Кара болыт кебек (булып)** — нәрсәнең дә булса күплегә турында әйткәндә кулланыла. *Урамның аргы башында кара болыт булып халык җыелып тора.* И. Гази. **Кара болыт каплау** — нинди дә булса кайгы, күңелсезлек булу, килү. **Кара гайбәт** — бик начар, эшәке гайбәт. *Теге акылсыз кыз минем эшем һәм үзем турында кара гайбәт таратып йөри башлаган.* А. Расих. **Кара ипи (икмәк)** — арыш оныннан пешерелгән ипи. *Җәмилә бер тәлинкә белән вак-вак телемнәргә тураган кара икмәк - - - чыгарып куйды.* М. Әмир. **Кара исемлек** — нинди дә булса шикле яки гаебе булган кешеләр теркәлгән, язылган исемлек. *Учительләр мәктәбеннән укып чыккан егетләрнең шактый өлеше полиция күзәтүе астында, „кара исемлек“тә торган хәлдә эшләп килделәр.* И. Рәмиев. **Кара исәп (хисап)** — күңелдән, якынча гына исәпләү. *Бераз кара исәп белән дә уйлап карарга кирәк: нәрсә чәчсәң, ничек уңар да, нәрсә чәчсәң, доходны кайсы күбрәк бирер?* Р. Төхфәтуллин. *Безнең кара хисапка караганда, „ат башыдай алтын“ бер исәпләгәндә йөз мең, икенче исәпләгәндә әллә ничә миллионга китте.* М. Гафури. **Кара йөз** — 1) исеме чыккан, хурлыкка калган кеше. [*Закир белән Галимәнең*] *йөзләренә каралар ягып, артларыннан: „Кара йөзләр!..“ дип кычкырулар күз алдыма килә.* М. Гафури; 2) усал, рәхимсез, кабахәт. *Кара йөз ул, кара эч ул һаман да, мәхәббәт һәм кешелек юктыр анда!* Г. Тукай. **Кара йөрәк** — эшәке, усал, астыртын эшләр эшләүче кеше. *Мин - - - ни эшләргә белмичә, - - - бу тасма телле кара йөрәкнең битенә төкерүдән - - - чак кына тыелып калдым.* С. Сабиров. **Кара козгын**— гаепләнүчеләрне йөртә торган махсус ябык машина. *Ул арада „кара козгын“ килеп туктады.* Ш. Маннур. **Кара көз** — көзен иң соңгы пычрак, салкын көннәр. *Бөгә алмады* [*урман*] *Сине көчлеләр, Җүйды яменне Кара көз генә.* З. Мансур. **Кара көнгә калдыру (саклау)** — берәр нәрсәне алда буласы авыр көннәр өчен саклау, калдыру. **Кара көнгә калу** — бөлүү, материаль яктан мохтаҗлык, авыр көннәр кичерү. **Кара көч**

полит. — барлык алдынгы, прогрессив нәрсәгә дошман караучы һәм иске тәртипләрне саклап калу яки кире кайтару өчен көрәшүчеләр. *Большевиклар партиясе: Сак булыгыз, кара көчләр революциягә каршы заговор коралар, ди.* И. Гази. **Кара көю** — 1) тәннең берәр урыны бәрелү, сугылудан каралу; 2) нинди дә булса сәбәп аркасында йөз, чырай караңгылану, бик кәефсез булу. [*Нургали*] *бөтен кешегә хәтере калгандай, кара көеп йөри.* Ә. Еники. **Кара күзлектән үткәрү (карау)** — бар нәрсәне дә начар итеп күрү, барлык өлкәдә дә тик җитешсезлекләрне генә күрү. [*Кайбер кешеләр*] *колхоздагы бөтен күренешләрне тик кара күзлектән генә үткәрәләр.* Сов. әд. **Кара күмергә калу** — бөтенләй янып бетү. **Кара материк**— кара тәнле кешеләр, негрлар яши торган материк. **Кара мәче узу** — берәрсе белән ара бозылу, ачуланышу. [*Зәкия*] *Бибиҗамал апаның күңелен тынычландырырга тырышты. Ләкин* [*бу сөйләшү*] *ике туган арасыннан кара мәче узудан башканы бирмәде.* Ш. Хөсәенов. **Кара реакция** *тар.* — реакциянең иң катысы, иң рәхимсезе. *1905 елгы революция бастырылганнан соң башланган кара реакция кайбер катлауларда, бигрәк тә буржуа - - - интеллигенциясе арасында өметсезлек тудырды.* М. Җәлил. **Кара сакал** — мохтаҗлык, бәхетсезлек. *Кара сакалның һәрвакыт үзе белән йөргәнлегенә* [*Садыйк*] *бик тиз ышанды.* А. Расих. **Кара такта** — артта калучылар яки нәрсәдә дә булса гаепләнүчеләр исеме кертелә торган такта. *Наташаның ире бригадир булып эшләгән. Тик бервакыт аның башы кара тактадан чыкмый башлаган.* Г. Бәширов. **Кара тир түгү**—бик нык, ару-талуны белми эшләү, бик нык тырышу. [*Хурлыклы тамганы*] *җую өчен Шәвәлигә революциягә чаклы да, революциядән соң да кара тир түгеп эшләргә - - - туры килде.* Г. Ахунов. **Кара тиргә батып эшләү** — *к.* кара тир түгү. *Кара тиргә батып эшләгәндә, кинәт породаларны актарып шахта суы килеп чыкты.* И. Гази. **Кара ягу** (кешегә) — гаеп ташлау; кемне дә булса яманлау, хурлау, начар итеп күрсәтү. [*Хәмдия Әлфинурга:*] *сөйләмә юкны, изге күңелле балага кара якма син.* Р. Ишморат. [*Давыт прокурорга:*] *Минем өскә кара яккан өчен тагын ике-өчне өстисегез калган.* А. Гыйләҗев. **Кара эчле** — мәкерле, явыз, әшәке (кеше). [*Габдулла*] *кешеләрнең шундый мәкерле, тиз аңлап булмый торган кара эчле булуына бөтен йөрәге белән рәнҗи.* Ш. Маннур. **Кара яну** — 1) *к.* кара көю. [*Васяның*] *кыйналудан бөтен тәне тимгел-тимгел булып кара янган иде.* А. Шамов; 2) җиләк-җимешнең гадәттәге төстән куерак булып пешүе турында. *Өлгереп килгән зур-зур кызыл алмаларга, кара янып пешкән чияләргә... бик озак карап торды* [*кызылармеец*]. И. Гази. **Кара җәяү калу** — бөлеп бетү, бернәрсәсез калу. *Әпипәне - - - Чистай пристанендa кара җәяү калдырып, ташлап киткән, ди теге.* Г. Бәширов. **Карасына бату (кабыну)** — караңгы чырайлы булу, күңелсез, кәефсез булу. [*Искәндәр*] *карасына батып утыра.* М. Фәйзи.

КАРА II *и.* Язу өчен кулланыла торган берәр төрле буяу эретеп ясалган сыеклык. *Зәңгәр эчле ак конверттан, шома - - - кәгазьгә кара белән язылган кечкенә записка чыкты.* М. Әмир.

КАРАБАИР: **карабаир аты** — Үзбәкстан һәм Таҗикстанда үрчетелә торган эссегә чыдам, ияргә, йөккә һәм җигүгә яхшы яраклашкан ат токымы. *Карабаир юрга.*

КАРАБАЙ *и.* Башкорт халык биюе һәм шул биюнең көе.

КАРАБАШ *и. бот. к.* җикән.

КАРАБИН *и.* Кыскартылган көпшәле винтовка. *Кылычым булса кынымда, Карабиным кулымда, Сине саклап, туган җирем, Мин ирләрчә үләр идем Данлы сугыш кырында.* М. Җәлил.

КАРАБИНЧЫ *и.* Карабин белән коралланган сугышчы. *Безнең карабинчылар, ат тояклары астыннан кар аттыра-аттыра,* [*бандитларны*] *куа киттеләр.* И. Гази.

КАРАБОДАЙ *и.* 1. Ике өлешләр семьялыгыннан хуш исле һәм баллы чәчәк ата торган игүле берьеллык үлән үсемлек. *Иген басуларында яшелле-көрәнле солылар, тарылар арасында карабодайның ак чәчәкләре җирне каплап, тирә-якны бал исе белән хушландыра башлаган.* Г. Ибраһимов.

2. Шул үсемлекнең өчкырлы орлыгы (ярма яки он хәлендә азык итеп файдаланыла). || *с. мәгъ.* Шуннан хәзерләнгән. *Комиссарның борынын кытыкландырып, карабодай боткасы исе килде.* М. Әмир.

КАРАБОДАЙЧАЛАР *и. бот.* Карабодайга охшаш үсемлекләр семьялыгы. *Кузгалак — карабодайчалар семьялыгына керә торган күпьеллык үсемлек.* Җиләк-җимеш.

КАРАБҮРЕК *и. зоол.* Зур булмаган урман кошы (аталарының түшләре кызыл була); *русчасы:* снегирь. *Ә теге кызыл күкрәкләләре — карабүрекләр.* Ялкын.

КАРАВАЙ *и. сөйл.* Мич төбенә салып пешерелгән түгәрәк ипи. *Олаучы икенче капчыгыннан бер каравай икмәк чыгарды.* И. Туктар.

КАРАВАТ *и.* Йоклау өчен хезмәт итә торган дүрт аяк беркетелгән озынча рама формасындагы өй җиһазы. *Каравать буенда гына түгел, хәтта идәннәренә дә келәмнәр җәелгән.* М. Хәсәнов.

КАРАВЫЛ *и.* 1. Кораллы дежурлык, кизү, сакта тору. *Каравылда тору. Каравыл кую.* □ *Лейтенант белән Беляев кемнең кайда урнашуын исәпкә алу һәм каравыл оештыру өчен сугышчылар арасында калдылар.* М. Әмир. — *Бер кеше каравылда булса, без башкаларны уятмыйча ук китеп бармакчы булган идек.* Ш. Камал.

2. Каравыллау вазифасы. *Елның елында безнең әти Шәфыйк бабай белән бергәләп каравыл ала. Инде хәзер: „Каравыл алган кеше үзе ат куйсын“, — дип әйтәләр, ди.* М. Гали. — *Мин дозор - - - басу каравылын комсомол миңа тапшырган.* Г. Бәширов.

3. *җый. и.* Кораллы сакчы (лар), сакта торучы кеше(ләр). *Залга гаепләнүчеләрне керттеләр. Алдаартта мылтыклы каравыл.* Г. Ибраһимов. *Юлны карап килергә бер-ике җәяүле каравыл чыгарылды.* Ш. Усманов.

4. *ы. мәгъ. сөйл.* Талаучы яки кыйнаучы һөҗүм иткәндә, шулай ук бүтән берәр бәла-каза килгәндә ярдәмгә чакыру өчен кычкырыла. — *„Каравыл!“ дип урамда бандитлар талаганда гына кычкырганнар.* А. Расих.

Каравыл алу — кулындагы коралны билгеле бер рәвештә тотып яки хәрәкәтләндереп, хәрби тәртип буенча өлкәннәрне сәламләү. **Каравыл астында** — сакчылар күзәтүе астында. *Фәхри бабайны бер як читкәрәк алып киттеләр. Ул берничә кешенең каравылы астында.* М. Гафури. **Каравыл базы** *иск.* — кулга алынган гаепле кешеләрне вакытлыча ябып тоту өчен казылган ябулы чокыр, баз *(3 мәгъ.).* [*Хөсәен:*] *Бүген урманга китүчеләрнең - - - ата-ана, кардәш-ыруларын каравыл базына!* Ф. Бурнаш. **Каравыл йорты (өе, балаганы һ. б.)** — 1) *иск.* авылның җәмәгать милкен саклау, каравылчылар кереп йөрү һәм мир җыелыны үткәрү, шулай ук гаепле кешеләрне вакытлыча ябып тоту өчен файдаланыла торган өе. *Каравыл йортына халыкның яртысы гына сыйды. Калганнары ишек алдында кар таптыйлар.* К. Нәҗми. *Закир абыйны каравыл өеннән алып чыктылар.* М. Гафури; 2) каравыл постларыннан кайтып ял итү, ашау-эчү

өчен билгеләнгән һәм каравыл начальнигының төп хезмәт урыны булган өй, бүлмә. *Училище территориясенең иң читендә, каравыл өеннән километр чамасы читтә бер печән кибәне бар иде.* М. Әмир. **Каравыл лапасы** — каравыл өе янында җәмәгать кирәк-яраклары, янгын сүндерү дирбиясе саклана һәм җәмәгать кизүендәге атлар тора торган каралты. *Мәйданга, каравыл лапасы каршындагы сулы мичкә янына, бер төркем кеше җыелган иде.* Ш. Еникеев. **Каравыл салу** — 1) кемне яки кая булса да чакырып кычкыру, сөрән салу. — *Яхшылык белән тыңламыйсың икән, менә хәзер каравыл салып кычкырам да, халык җыеп, адәм хурына калдырам.* М. Шабай; 2) тревога күтәрү, берәр хәвеф-хәтәр барлыгын кешеләргә белдерү. *Хәкимов [ның] эчендә нәрсә барын белгән булсам, [аны] сайлаганда ук каравыл салган булыр идем.* М. Шәйми. **Каравыл сукыры** — *к.* тавык күз. **Каравыл тавы** — 1) борынгы заманнарда дошман явы килүен сагалап, күзәтеп тору урыны — гадәттә нинди дә булса табигый биеклек, тау; 2) соңрак — яшьләрнең билгеле бер калкулыкка җыелып үткәрелә торган язгы уеннары. *Татарда --- сабан туе, җыеннар, кыз туйлары, таган асты, карга боткасы, өмәләр һәм һәр якның юлык, каравыл тавы дигән кебек үз җыен-бәйрәмнәре дә булып алган.* Н. Исәнбәт. **Каравыл тору** — билгеле бер урында сакчы булып яки сакчы кебек тору. *Юан таяк тоткан бер таза егетнең тәүлекләр буе диярлек Хафиз кибете алдында каравыл торуын күрделәр.* Ә. Фәйзи.

◇ **Каравыл кычкыртып** — ай-ваена карамыйча, мәҗбүри рәвештә, көчләп. *Сөләйманны каравыл кычкыртып, --- өстән биклəп киттеләр.* К. Тинчурин.

КАРАВЫЛЛАУ *ф.* **1.** Берәр объектны һөҗүмнән, төрле фетнә яки бәла-казадан, караклардан саклап тору. *Амбар каравыллау. Басу каравыллау.* □ *Хафизулла карт каравыллый торган ферма авылдан өчдүрт километр җирдә --- чокыр-чакырлар арасында иде.* Ф. Хөсни. || *күч.* Берәр нәрсә янында эшсез вакыт үткәрү турында. — *Давай китәбез, безгә бу башкорт авылын каравыллап ятудан файда булмас.* М. Гафури.

2. Качып чыгып китүдән саклап тору, күзәтү. — *Закир, Мөхәммәтҗан, сез шунда Сиражәтдинне яхшы гына каравыллап утырыгыз, бер җиргә дә чыгып китмәсен.* Г. Камал. || Көтү. *Малайларны үзем белән елга буена, болынга, бия каравылларга алып китәргә әзерләнә башладым.* Г. Ибраһимов.

3. Тәртип-йола буенча кемдер янында утыру; карау, карап тору. *Утның саран яктысы төн буенча үлгән эшченең гәүдәсен һәм аны каравыллап утырган картларның җыерчыклы битләрен яктыртып торды.* М. Гафури.

4. Сагалап, күзәтеп тору (йөрү). *Әнә Андрюша тычкан каравыллаган мәче шикелле утыра.* К. Латыйпов. — *Кара әле, Марат, нигә син мине каравыллап йөрисең?* Т. Гыйззәт.

КАРАВЫЛЧЫ *и.* **1.** Каравылда торучы, даими сакчы. *Бикә --- малга бүре тия, салам вә игенне бик урлыйлар дип, йортка каравылчы да куя.* Г. Ибраһимов. || Авыл халкы йоклаган вакытта төрле бәла-казадан саклап, авыл буйлап йөрүче, урам сакчысы. *Төнге каравылчы. Урам каравылчысы.* || *с. мәгъ.* Хәрби каравыл постына куелган. *Зиндан капусы янында ук бер төнге каравылчы солдат стенага сөялеп гырылдап йоклamакта иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Кайбер коллектив уеннарда төп фигура — башкаларны эзләп табучы, куып тотучы, гөрләүче һ. б. *Каравылчы малайларны тотарга тырыша. Тотса, тотылган малай каравылчы булып, тотучы гади бер уйнаучы гына булып кала.* Н. Исәнбәт. *Таккаравыл уйныйлар --- Каравылчы кычкыруга як-яктан бер кыз белән бер малай йөгерешеп чыгалар.* И. Гази.

КАРАВЫЛЧЫЛЫК *и.* Каравылда тору эше яки вазифасы. *Хәлил үзе Мәрфуга терелгәнче дип, монда каравылчылыкка ялланып, аның белән калган.* Ш. Камал.

КАРАВЫШ *и. тар.* Ханәкәнең (хан кызының) хадимәсе, хезмәтче кызы. *Зөләйха әйдер: каравышлар җөмләсе хазыйрь килсен.* Колгали.

КАРАГАЙ I *и.* **1.** Көз көне ылысын коя торган агач. *Карагаен күрдем тайгаларның, Усакларын күрдем Усаның.* Х. Туфан. *Кайчандыр биредә кара урман булган, диләр. Хәзер исә ялгыз карагайлар гына анда-санда күренгәли.* М. Шабай.

2. *диал.* Нарат, чыршы. *Тайга йокысыннан уянып килә. Кояшның алсу нурлары зифа буйлы карагайларның бозлы инәләрендә җем-җем килеп уйныйлар.* Г. Мөхәммәтшин.

КАРАГАЙ II *и.* Кыр үрдәгенең кара каурыйлы бер төре; *русчасы*: чернеть. *Бездән ерак та түгел, камыш арасында бер карагай күренде.* Ак юл.

КАРАГАЙЛЫК *и.* Карагайлар күпләп үскән урын, карагай урманы. *Безнең авыл, сезнең авыл: Арасы карагайлык. Кавышаек, дустыкаем, Ятларга карамаек.* Җыр.

КАРАГАНДА *бәйл. юн. кил. белән кулланыла.* „Белән чагыштырганда“ мәгънәсен белдерә. *Минем әни этигә караганда үткер, җитез, күбрәк сөйләүчән кеше.* М. Гафури. *Җитмәсә дошман безгә караганда берничә тапкыр күбрәк.* Г. Гобәй.

КАРАГАТ *и. диал.* Кара карлыган. *Карагат кагы.* □ *Күзкәйләреңнең карасы Карагатлардан кара.* Җыр. *Ул елларда --- җиләк-җимеш исәп-хисапсыз иде. Нарат җилгән, эрбет чикләвеген, карагатны ат йөге белән ташыйлар.* Ш. Маннур.

КАРАГАЧ *и.* Элмәсыманнар төреннән бер агач — урта пояснең җылырак урыннарында үсә.

КАРАГРУҺ *и.* **1.** Патша Россиясендә монархист, шовинист, үтә реакционер. *Карагруһ-погромчылар төркеме, тәкбир әйтә-әйтә, кара болыт төсле урамны тутырып, мәдрәсәгә таба якынлаша.* К. Тинчурин. *Карагруһлар вә аларның газеталары думаны куу тугрысында сөйләнүдән туктамыйлар.* „Урал“. *Татар карагруһлары үз --- әдәби хәрәкәтләрен тудыра алмадылар.* Г. Нигъмәти. | *с. мәгъ. Консерватив руханилар, карагруһ буржуазия һәм алпавытлар халык арасыннан чыккан җыр-музыка талантларына каршы ерткычларча көрәштеләр.* М. Җәлил.

2. Революциядән соң социалистик үзгәрешләргә каршы торган реакцион группалар. *Икътисади мәсьәләләрдә советның болай эшне кыска тотуы алпавытлар, байлар, карагруһларга бер дә ярамады.* Ш. Әхмәдиев.

КАРАГРУҺЧЫ *и.* Карагруһ оешма члены; үтә реакцион, контрреволюцион катлам вәкиле. *Җыелышлар тыелды. „Правда“ны яптылар. Карагруһчыларның үлем алдындагы тыпырчынулары бу.* К. Нәҗми.

КАРАГРУҺЧЫЛ *с.* Карагруһчыларга хас булган. *Бу [1909 — 1911 нче] еллар өчен карагруһчыл шовинизмның котырынуы һәм милләтчелекнең үсүе характерлы булды.* И. Нуруллин.

КАРАГРУҺЧЫЛЫК *и.* Карагруһ тарафдары булу; карагруһлар хәрәкәте. *Тукай иҗатында --- карагруһчылык идеологиясенең һәртөрле күренешләренә каршы нәфрәт идеясе үсте.* Г. Халит.

КАРАГЫСЫЗ *с.* Карарлык түгел, карарга куркыныч. *Адәм карагысыз.* □ *Шофер егетнең өсте-башы кеше карагысызга әйләнде.* Б. Камалов.

КАРАЗИР *и.* Лютиксыманнар семьялыгыннан карасу чәчәкле бер үсемлек; *русчасы:* чернуха. *Болары әле әбинең эшләнмәгән дарулары иде. Боларның эчендә канәфгер дә, далчин дә (дарчин), каразир орлыгы да, зәгъфран да, тагын әллә ниләр, әллә ниләр бар иде.* Ак юл.

КАРАИМ *и.* Кырымда һәм Литвада яши торган аз санлы төркн халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. | *с. мәгъ. Караим теле.*

КАРАИ'МЧА *рәв.* Караим телендә. *Караимча сөйләшү. Караимча язылган китап.*

КАРАК *и.* **1.** Урлау белән шөгыльләнүче кеше, урлашучы; кеше әйберен, милкен үзләштерүче. *Ат карагы.* □ *Ходай орган караклар, уңмаганнар, Кесәмнән портмонетны урлаганнар.* Г. Тукай.

2. *с. мәгъ.* Урлаучан, урлаша торган, урлашуга һәвәсле. *Илдар баз баскан карак малай кебек куркынып, ботактан ботакка төшеп, җиргә сикерде.* Г. Гобәй.

КАРАКАЙ *и.* Карасу йөзле бала яки яшь кыз (яратып әндәшү сүзе). [*Хаҗия:*] *Син ни атлы, каракай?* Т. Гыйззәт. *Каракаем, карыйсың, Карап кемне таныйсың?* Жыр.

КАРАКАЛ *и.* Чүл мәчеләренең бер төре, киек кошларга һәм куяннарга ауга йөрү өчен кулга ияләштерелә.

КАРАКАЛПАК *и.* Каракалпак АССР территориясендә һәм аңа чиктәш өлкәләрдә яшәүче төркн халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. | *с. мәгъ. Каракалпак теле. Каракалпак милләте. Каракалпак киеме.*

КАРАКАЛПАКЧА *рәв.* Каракалпак телендә. *Каракалпакча сөйләү.*

КАРА-КАЛӘМ *җый. и. сир.* Кара, каләм, карандаш шикелле язу әсбаплары. *Мулла дәфтәрләрен, каракаләмнәрен букчасына тыкты.* Г. Ибраһимов.

КАРА-КАРШЫ *рәв.* **1.** Алгы яклары, йөзләре белән бер-берсенә карап. *Кара-каршы очрашу. Кара-каршы бию.* □ *Кайвакытта кара күзле, кара кашлы Матур белән утырамын кара-каршы.* Г. Тукай. *Кич белән тын елгада кара-каршы йөзеп килгән ике көймә күренде.* Г. Гобәй.

2. Бер-берсенә каршы як булып. [*Рефератны тикшерү*] *дошманнарның кара-каршы бәрешүләренә, талашуларына әйләнеп китте.* Г. Ибраһимов.

3. Җаваплашып, фикер алышып. *Бу турыда* [*мәхәббәтең турында*] *әти-әни белән кара-каршы сөйләшмиләр дә бугай.* Г. Бәширов. || Түләү, кайтару шарты белән. *Бәйрәм ашы кара-каршы.* Мәкаль.

Кара-каршы йорт — уртак түбә астында торган һәм ишекләре бер-берсенә караган ике бүралы өй (татар милли архитектурасына хас). *Сабир иптәш осталарны коры тотты, Кара-каршы итеп салды биек йортны.* Г. Афзал. **Кара-каршы җырлашу (җыр әйтешү) —** төртмә җырлар импровизацияләп, шигъри бәхәс алып бару. *Шул ук атна кичләрне шәкертләрнең кара-каршы җырлауларында да Габдулла алдынгылыкны бирмәде.* Ә. Фәйзи.

КАРАКА'ТИЦА *и.* Кыслаларга якын торган диңгез хайваны — моллюск.

КАРА-КАТЫШ *рәв.* Кискен аерымланып һәм бергә, аралаш. *Өй җиһазлары иске заман нәрсәләре белән кара-катыш, стенада рамкалы язулар.* Г. Камал.

КАРАКАШ *и.* Кара кашлы хатын-кызга яки егеткә иркәләп әйтү сүзе. — *Каладагы кебек читек-кәвеш киеп, „керт-керт“ кенә басып йөрүче кем дисәләр, ул минем Наилә каракаш булыр.* Ф. Хөсни. *И минем каракашым, Ятасың ялгыз башың, Бу хәлләр ничек, Камәр, Йөрәкне яндырмасын.* Х. Туфан.

КАРАКЛАНУ *ф.* Карак булып китү; караклык итү. *Үзең укып йөр, үзең караклан, кеше әйберсенә кул суз* [*имеш*]*!* Ш. Маннур.

КАРАКЛАРЧА *рәв.* Каракларга хас булганча. *Каракларча ялт-йолт карану.* □ *Каракларча яшеренеп кергән дошман үз эзләгәнен табарга* [*тар-мар ителәргә*] *тиеш.* Г. Кашшаф.

КАРАКЛЫК *и.* Урлашу шөгыле, урлау. *Карак караклыгын куйса да, карак аты онытылмас.* Мәкаль. — *Бала-чагаларыбыз, бер кыяр кабарга зар булып, караклыкка өйрәнәләр.* М. Әмир.

КАРАКОРТ *и.* Урта һәм Үзәк Азиядә, чүлләр зонасында очрый торган агулы үрмәкүч. *Каракортлар кебек Агу чәчеп Ябырылдыгыз гөлле җиремә.* Х. Мөҗәй.

КАРАКОШ *и.* Карчыгасыманнар семьялыгыннан зур ерткыч кош, кара бөркет. *Каракошның оясы коры булмас.* Мәкаль. *Сөям, дустым, каракошның, таудан ашып, Болытларда мәгъруранә кагынганын.* Ш. Мөдәррис.

КАРАКУРА *и.* Биек булып үскән чүп үләннәре. *Каргалган йортка каракура үсәр.* Мәкаль. [*Авылның*] *кыйшайтканнар еллар өйләрен, Каракура баскан күлләрен.* Сов. әд.

КАРА-КУЧКЫЛ *с.* Көрәнсу-кара. *Үләннәр дә каракучкыл, Көеп утта янганмыни!* Ш. Галиев.

КАРА-КУЧКЫЛЛАНУ *ф.* Кара-кучкыл булып китү; караңгылану, томанлану. *Акрын гына баткан кояшның күк йөзендә калдырган ялкынлы кызыллыгы каракучкыллана башлады.* Ф. Әмирхан. *Караңгы төште. Су кара-кучкылланып, дегеткә охшап калды.* М. Хәсәнов.

КАРА-КУЧКЫЛЛЫ *с. к.* кара-кучкыл. *Менә бер заман агачлар артыннан тау-тау ишелеп каракучкыллы болытлар агыла башлады.* С. Җәләл.

КАРАКЧЫ *и. иск.* Карак. *Өч бала: бәгъзесе, кулына чыбыркы тотып, мин көтүче булам, бәгъзесе мин урман саклыймын, бәгъзесе мин каракчы булам дип әйтәләр иде.* З. Һади.

КАРА-КӨРӘН *с.* Куе, караңгы көрән төстәге. *Бөгелмә сулары тирән, Төпләре кара-көрән.* Жыр.

КАРАКҮЗ *и.* Кара күзле кыз яки малай (иркәләп яки шаяртып әйтү сүзе). *Шулай да менә бу минутта - - - кайларда һәм ниләр эшләп йөргән була икән ул каракүз* [*Наҗия*]*?* Ф. Хөсни.

КАРАКҮЛ *и.* **1.** Урта Азиядәге каракүл токымыннан булган куй бәрәннәренең махсус эшкәртелгән тиресе, илтер. *Төркстан вә Бохарадан килгән ефәк, каракүл вә гайре малларның сумасы ничә миллионлык буладыр.* Ш. Мөхәммәдев. | *с. мәгъ.* Шундый тиредән эшләнгән. *Теге кешенең - - - башында һәйбәт биек каракүл бүрек,* [*өстендә*] *каракүл якалы тун.* К. Тинчурин.

2. Каракүл бүрек. *Байлар киде каракүл, Ярлы киде эшләпә.* Г. Камал. *Кимә камчат, ки каракүл, Бәгърем, кырын сала күр!* Жыр.

КАРАКҮЛЧЕ *и.* **1.** Каракүл бүреклəр, якалар һ. б. тегүче. [*Гыйсмәтне*] *атасы Мәскәүдәге бер авылдашы каракүлчегә малай итеп җибәргән - - -* [*ул*] *анда бүрек тегәргә өйрәнгән.* Г. Гали. || *иск.* Каракүл белән сәүдә итүче татар сәүдәгәре. — *Кибетең матур, җиһазлары ару, каракүлчеләрдә тагын мондый кибетләр бармы икән?* Г. Әпсәләмов.

2. Каракүл куйларын (сарыкларын) асрау белән шөгыльләнүче кеше.

КАРАКҮЛЧЕЛЕК *и.* Каракүл куйлары асрау һәм каракүл хәзерләү белән шөгыльләнә торган хуҗалык тармагы. *Авыл хуҗалыгы институтының каракүлчелек бүлеге.*

КАРАЛАЙ *рәв.* Кара булып; кара көенчә. *Ак бүреләрнең [ыруг исеме] йөзе каралай янып чыкты.* Н. Фәттах.

КАРАЛАМА *и.* Акка күчерелмәгән, эшкәртү-төзәтү процессында булган язу-сызулар. *Караламаны акка күчерү.* □ *Либретто язылып бетмәгән - - - каралама хәлендә генә иде.* М. Җәлил. | *с. мәгъ. Каралама кульязма. Каралама эскизлар.*

КАРАЛАНУ *ф.* Берәр нәрсәгә буялып каралу; кара төскә керү. *Кайбер бүлмәләрнең ишек башлары кумерләнеп караланган.* Ш. Камал. || Керләнү. *Минем өстем тузган, ертык-пыртык, Караланган керле күлмәгем.* М. Җәлил.

КАРАЛАУ *ф.* 1. Карага буяу, каралту. *Тешләреңне каралама, Кашларыңны карала.* Җыр.

2. *күч.* Кайгылы-хәвефле итү; пычрату. *Маташмагыз якты көнне караларга, Дошманлык салырга дип араларга.* Г. Камал. || Яла ягу, начар итеп күрсәтү. *— Син мине ялган, буш сүзләрең белән каралый алмассың, — дип җикеренде Әхмәди.* Г. Иделле.

КАРАЛЕ *ы.* 1. Игътибар итәргә кирәклекне белдерә һәм төрле аһәң, төрле тон белән әйтелә. *— Бибигазизә, карале, мин кемне алып кайттым сиңа? — дип мактанып алды Мөхәммәтвәли абзый.* Ә. Фәйзи. [*Биби:*] *Карале, ә, кем, Гайни!* Г. Камал.— *Карале, Галиуллә,— диде Якуб, — синдә мылтык юкмы?* И. Гази.

2. Гаҗәпләнүне, соклануны, таң калуны белдерә. *Хәзер Наташа әйтә: „Карале, анда безнең үзебезне өйрәтә башладылар".* Г. Бәширов.

КАРАЛТУ *ф.* 1. Кара төскә кертү; карага буяу. *Янгын - - - салам түбәне бераз көйдереп, каралтып куйды.* Г. Ибраһимов. *Ай урагы кебек кашларыңны Кем бәхтенә шулай каралттың?* Н. Исәнбәт. || *махс.* Металл өстенә тутыкны үткәрми торган кара окись йөгертү. *Урмановның күзләре каралтылган корыч кебек ялтырый.* Г. Әпсәләмов.

2. Кара-тутлы итү. *Бу вакытта аның [Шәйхәттар бабайның] язгы җил каралткан җыерчыклы йөзендә һәркайчан була торган елмаю юк иде.* Г. Гобәй.

3. Керләндерү, пычрату. *Киемне каралту. Идәнне каралту.* □ *Аклы күлмәк якаларын Кимичә каралтмагыз.* Җыр.

4. *күч.* Кайгыга төшерү; төшенкелек китерү, бәхетсез итү. *Әллә нинди бер күңел каралткыч караңгылыкка чумган бу атау.* Ф. Әмирхан. *Каралтырга уйлап якты көнебезне, һөҗүм итә көнбатыштан кара болыт.* Ә. Исхак.

КАРАЛТЫ *и.* Төрле хуҗалык корылмалары: абзар-кура, амбар-келәт, мунча, лапас, әвен һ. б. *Каралты— түбә белән, адәм — кием белән.* Мәкаль. *Өй тәмам булгач, Захар үзенең ишек алдын барлык кирәкле каралты белән әйләндереп алу хәстәрен дә күрде.* М. Әмир. *Сулдарак чүлмәк түбәле каралтылар: кирпечтән салынган биек силос манаралары, киң тәрәзәле җәенке араннар, водопровод башнясы.* Г. Бәширов.

КАРАЛТЫ-КУРА *җыйд. и.* Төрле каралтылар. *Бакча киртәләре, каралты-кура түбәләре яңгыр яумаганда да ничектер дымланып торган кебек күренәләр.* Ф. Хөсни.

КАРАЛУ I *ф.* 1. Кара төскә керү, караңгылану. *Чана юллары беләүләнеп шомардылар, аннан караддылар.* Г. Гобәй. || Кара-туткыллану. *Володяның җилдән, кояштан каралган йөзе көлә, күзләре чак кына кысыла төшеп, каядыр ераккa-ераккa карыйлар иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Керләнү, пычрану. *Каралып беткән сәләмә шахтерлар рудник тирәсендә дәрья кебек дулкынлана, кайный иде.* Ш. Камал. *Хәмдиянең ак калфагы Яңа каралган чагы.* Җыр.

3. Кара, караңгы төстә күренү. *Ул [Айсылу] юлдан бераз читтәрәк каралып күренгән агачлык төркемен күрсәтте.* Г. Бәширов. *Куе урманнар, Кара диңгез кебек булып Каралып һәм дулкынланып, Шаулап торганнар.* Ә. Исхак.

4. *күч.* Наданлану, рухи яктан тупаслану. *Ә безнең ишеләр - - - гөнаһка чумып, каралып бетә.* К. Тинчурин.

КАРАЛУ II *ф.* 1. *Төш. юн. к.* карау.

2. Сәламәтлек, саулык ягыннан тикшерелү, медицина комиссиясеннән үтү (гадәттә солдатка алынучылар турында). *Бүген каралырга барачак бер егет, гармонь уйнап, җырлап килә.* Г. Гобәй.

3. Тиешле төзеклектә тотылу, төзекләндерелү; төзәтелү, тазартылу. *Ишек алдындагы өе әле яңа салынган, ак өй. Хәер, ул әле тиешенчә каралмаган да: түбәсенә туфрак салынмаган, эчтән нигез өелмаган.* Г. Толымбай. *Ел буе һичкем тарафыннан каралмаган кое нык чүпләнгән.* С. Рафиков.

КАРАЛЫ *с.* 1. Карага манылган, кара төстәге яки кара бизәкләре, кара буйлары күп булган. *Каралы күлмәк.* | *и. мәгъ. Аклылары акка калсын, Каралыны киегез.* Җыр.

2. Парлы кушма сүзләрнең беренче компоненты кара төс белән башка төс аралашып ясалган чуар төләрне белдерә, мәсәлән: **каралы-кызыллы, карал күкле.** □ *Поезд һаман кызудан-кызу алга йөгер Каралы-сарылы шакмакланган чәчү кырлары чиксез зур граммофон пластинкасы әйләнеп торган шикелле.* Ш. Камал.

КАРАЛЫК *и.* 1. Кара булу сыйфаты. *Каралыгына киная итеп, аны [Баязитны] „чуенның ундүртенче кичәсе" дип йөртәләр.* Б. Камалов. || Караңгылык. *Төн караңгы, җир-күк куе каралык эченә кереп югалган.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Наданлык, аңсызлык. *Наданлык, каралыкт череп беттек, Гыйлем белән үзебезне саклау кирәк.* Г. Камал.

3. *күч.* Мораль җитешсезлек, әшәкелек, күңелсезлек. *Өй эчендә бер генә минут тору да күңелгә авырсымак тоела, күңелгә каралык китерә төсле.* М. Гафури.

КАРАЛҖЫМ *с. ким. дәр. к.* кара. *Каралҗым урман.* □ *Йолдызлар каралҗым зәңгәр хәтфә өстенә чәчелгән энҗе бөртекләре төсле күк йөзен бизәп, тетрәгән хәлдә ялтыраша иделәр.* Ш. Камал. *Ут капкан йортларның ишек-тәрәзәләреннән сумала агымы төсле куе каралҗым төтен бөркелеп чыга.* К. Нәҗми.

КАРАМА *и.* 1. Элмәсыманнар семьялыгыннан киң ябалдашлы агач. *Корт иле кыр буендагы карама агачына килеп сара.* Ф. Хөсни. || *с. мәгъ.* Шул агачтан эшләнгән. *Карама дуга, кара юрга, Каян алдың бу атны?* Җыр.

2. Йомшак, сыек агачтан, гадәттә яшь карамадан бөгелгән һәм арба, чана кебек әйберләрнең аерым кисәкләрен беркетеп тора торган бөгәлҗә. *Чана карамасы.* □ *Мирвәли ике кулы белән дә арбаның шомарып, ялтырап беткән сөяк төсле арт карамасына ябышып бара иде.* А. Гыйләҗев.

Карама бөгү — арба-чана карамалары ясау. *Анда, сукыр лампа яктысында, Шәпи һәм бер малай, кайсы карама бөгеп, кайсы юкәдән бау ишеп маташа иде.* Г. Гобәй.

◇ **Карама көленә утыру** *сир.* — бик нык алдану, төп башына утырып калу. *Гитлерчылар бу эшне бик соң абайладылар һәм, карама көленә утырып калуларын күреп, ачуларыннан шартлар хәлгә життеләр.* Г. Әпсәләмов.

КАРАМАЙ *и. диал. к.* нефть. *Тышта, төн карасын ярып, багана башларындагы пыскыйларда карамайлар янды.* Н. Фәттах.

КАРАМАК *и. кыек килеш. форм.* Берәр шәхеснең яки оешманың ихтыяры, биләве, җаваплылыгы яки житәкчелеге. *Дәүләт карамагындагы милек.* □ *—Митрофан Петрович, иптәш Дияровны сезнең карамакка тапшырам, — диде Кожанов.* Г. Ахунов. *Мәсәл, бер ишарә биргәч, [мәгънә чыгаруны] укучының үз карамагына калдыра.* Х. Госман. || Вакыт турында. *Минем карамакта, — диде Закир, сәгатенә күз ташлап, — бер сәгать тә ун минут.* Г. Минский.

КАРАМАЛАУ *ф.* Арба-чанага карамалар кую. *Карамалының кара малаена чана карамалатырга биргән идем; карамалады микән, карамаламады микән.* Тизәйткеч.

КАРАМАЛЫК *и.* Карама агачлары күпләп үскән җир. *Тау башлары, ай-һай, бишек, Тау буе карамалык.* С. Сөләйманова.

КАРАМАСТАН 1. *рәв.* Нәрсәгә булса да игътибар итмичә. *— Сез, һичнәрсәгә карамастан, бүген төнлә бу авылдан китәргә тиешсез.* Г. Ибраһимов. *Сүзне Иван Иванович алды. Ул --- бернигә дә карамастан --- әшне дәвам итәргә тәкъдим итте.* А. Расих.

2. *бәйл.* Юнәлеш килешендәге сүз янында килеп, кире җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Март урталары җитүгә карамастан, кыш әле сынын нык тота.* Ф. Хөсни.

КАРАМЧЫК *и.* Тонык кара тап, силуэт; карачкыл. *Уң якта, бик ераста, кыр өстеннән аз гына калкып, соры карамчык булып бер авыл күренә.* Г. Бәширов. *Яңгыр астыннан бер карамчык чыгып, тәрәзгә якынайды.* А. Гыйләҗев.

КАРАМЫК *и. иск.* Кара чәчәк авыруы. *Бәхете караның боламыктан теше сынар, баласына карамык чыгар.* Мәкаль.

КАРАМЫШ *и. иск.* Караш, карап тору рәвеше. *Кызның кыйгач кашлары, күз карамышлары шулкадәр җазибәле иде.* З. Һади.

КАРАНДАШ *и.* Агач тышча киертелеп, графиттан яки башка коры буяудан ясалган таякчык (язу-сызуда кулланыла). *Карандаш очлау. Кызыл карандаш.* □ *Уеннан туйганнан соң, ак кәгазь белән бер башы кызыл, бер башы зәңгәр булган ике башлы карандашымны алам да рәсем ясый башлыйм.* З. Бәшири.

◇ **Карандаш (каләм) очына алу** — язып, теркәп кую. *Бер фикер тудымы — карандаш очына ал.* Г. Әпсәләмов.

КАРАНТИН *и.* 1. Йогышлы чир таралмасын өчен авыруларның башкалар белән аралашуын чикләү чаралары системасы.

2. Хәрби хезмәткә алынганнарны вакытлы изоляциядә тоту чоры. *Ун көнлек карантинны үтүгә, безне шундук полк мәктәбенә билгеләделәр.* Ф. Хөсни. *Карантин һәм башлангыч хәзерлек уздырганнан соң, сугышка яраклы солдатлар Едино лагерена күчерелеп, ант иттерүләр башланды.* Ш. Маннур.

КАРАНУ *ф.* Алмаш-тилмәш төрле якка карау. *Тирәюньгә карану. Як-якка карану.* □ *Нигъмәт алай-болай каранды да, үзенчә, бер кызык эшләргә булды.* Ф. Кәрим. *Урманнан карана-карана Вәли бай улы Габдулла килеп чыкты.* Һ. Такташ.

КАРАР *и.* 1. Уйланган ният; төпле фикер. *Какшамас карар. Кискен карар.* □ *Җиде уйдан бер карар, сигезенче уй — зарар.* Мәкаль. *Газинурның карары нык. Аның күңелендә курку да, тетрәү дә, икеләнү дә юк.* Г. Әпсәләмов.

2. Махсус тикшерү, киңәшләшүдән соң туган нәтиҗә, эш планы яки йөкләмә. *Карар проекты. Карар чыгару. Карар кабул итү. Карарны үтәү.* □ *Карарны яклап тавыш бирергә нәүбәт җиткәч, җыелышның зур күпчелеге бердәм рәвештә кул күтәрде.* Ф. Хөсни. *Партиянең карарлары партия членнары өчен иң югары закон хисаплана.* Ш. Камал. || Суд хөкеме. *Килер ул көн, халык хөкем итәр, Карар булыр кискен һәм кыска. Каным белән язган соңгы җырым, Бул гаеплау акты фашистка.* М. Җәлил.

3. Билгеле бер нәтиҗәгә яки ачык фикергә килеп тынычлану, канәгатьләнү. *Ул [Мавия] байлыкта да, мәхәббәттә дә карар таба алмаган кыз.* М. Фәйзи.

Карар бирү (беркетү) — ник уйлап ният итү. *— Без, иптәшләр белән сөйләшеп, туйны иртәгә үк ясарга карар бирдек.* Ф. Бурнаш. *Ике уйла, бер көт, шуннан карар беркет.* Мәкаль. **Карар итү (кылу)** — берәр фикерне раслап, гамәлгә куярга ният итү. *Карар иткән, үгез җиккән, Каф тавына җиткән.* Мәкаль. *Челюскинчылар фәнни эшләрне туктатмаска карар кылалар.* А. Алиш. **Карар салу** *иск.* — карарга килү, карар итү. *Карар салып, ишәк китте кырга атлап.* М. Гафури. **Карарга килү** — уйлаганнан соң берәр уй-фикергә килү. *Разведчиклар камыш эчендә чүгәләп киңәшкәч, мондый карарга килделәр; сугышмыйча мөмкин түгел.* И. Гази.

КАРАРЛАНУ *ф.* Ачык фикергә, ныклы бер карарга килү. *Хәмидәнең күңеле һаман карарланмый иде.* М. Гафури. *[Миргали] Бикташев алдында җиңелеп калу гарьлеге белән үлү уеннан кайта да каршылыкны, һөҗүмне дәвам иттерергә карарлана.* М. Җәлил.

КАРАРЛАШУ *ф.* Ныгып урнашу, тәмам кабул ителү (билгеле бер тәртип, кагыйдә һ. б. турында). *Татар теле грамматикаларында сүз төркемнәре ун төрдә карарлашты.* В. Хангилдин.

КАРАРЛЫ *с.* Төпле, ышанычлы; боерулы. *Кар суы юлын табар, Карарлы кол йолым табар.* Мәкаль. *Мохтар карарлы тавыш белән; — Ләкин моннан болай күрәләтә җәберләтергә һич ярамый, — диде.* Ш. Камал.

КАРАРЛЫЛЫК *и.* Төплелек, ышанычлылык. *Дунаевның зәңгәрсу күзләреннән эшчәнлек, карарлылык, кискенлек чәчелеп тора.* Ш. Камал.

КАРАРСЫЗ *с.* Тынычсыз, икеләнүчән, билгеле бер карарга килә алмаган. *Мавия --- әллә нинди карарсыз бер хәлдә күренә.* М. Фәйзи.

КАРАРСЫЗЛАНУ *ф.* 1. Тотрыксызлану, зәгыйфьләнү, көчсезләнү. *Минем бөтен гәүдәм, җиңеләеп, очып китәр төсле карарсызланды.* Ф. Әмирхан.

2. Икеләнеп калу; тотнаксызлык күрсәтү.

КАРАРСЫЗЛЫК *и.* Тотнаксызлык, ышанычсызлык, икеләнүчәнлек. *Ленин һәм большевиклар бу [вак буржуаз] партияләрнең яхшы элементларының карарсызлыгын сындырып, аларны кискенрәк революцион хәрәкәтләргә тарту юлында эш күрүне тиеш таптылар.* Г. Нигъмәти.

КАРАСАКАЛ *и. этн.* Кыпчак халыкларында — кыргызларда, казакъларда һ. б. шулай ук борынгы татарларда урта яшьтәге ир кеше. *Икенче сафта карасакаллар — ир уртасы казакълар [утыра].* И. Салахов.

КАРАСУ *с.* 1. Кара төс катышкан, карага тартым; каралҗым. *Землянкалар тирәсендә ботаклары җиргә таба тартылып торган карасу чыршылар үсә.* Г. Әпсәләмов. *Сестра, карасу күзләрен тутырып, күтәрелеп карады.* А. Шамов. || Кара-көрән, кояшта каралган (тән төсе турында). *Карасу йөзле бер кеше каты басып миңа таба килә.* Г. Ибраһимов.

2. Парлы кушма сыйфатларның беренче компоненты. Билгеле бер төсләрнең карангырак төрдә булуын белдерә, мәсәлән: **карасу-зәңгәр, карасу-кызыл.** □ *Кичәге, өченче көнге яңгырлардан һаман да кип-*

шенергә өлгермәгән карасу-саргылт өйләр - - - тагын да кечерәеп калгандай күренәләр. Р. Төхфәтуллин. *Карасу-яшел ылыс белән капланган чыршы ябалдашлары шундый калын, шундый куе.* М. Әмир.

КАРАСУЛАНУ *ф.* Карасу төскә керү. *Мансурның күзләре зәңгәр, ләкин вакыт-вакыт карасуланып китәләр.* Г. Әпсәләмов.

КАРАСЫЛУ *с.* Тумыштан ук карасу тәнле (хатын-кыз турында). *Кызларның икесе карасылу, гәүдәгә, коеп куйган сындай, ныкча иде.* Х. Сарьян.

КАРАТ *и.* Асылташларны (алмаз һ. б.) үлчәү берәмлеге —0,2 грамм.

КАРАТА *бәйл.* **1.** Юнәлеш килешендәге исем янында килеп, эш-хәрәкәтнең кемгә, нәрсәгә юнәлдерелүен белдерә: мөнәсәбәттә; мөгамәләдә. *Кешеләргә карата гаделлек таләп итү — коммунистлыкка каршы килә́мени?* М. Әмир. *Капитан Газинурга карата артык каты кылана иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Кемгә дә булса мөрәҗәгать итеп, атап, каратып. *Дивизия башлыгы губернаторның солдатларга карата язган фәрманын укый башлады.* М. Гафури.

3. Кем, нәрсә турында, хакында. *Президиумда утырган Озын Талип Бакайның үзенә карата мондый сорау бирде.* Ш. Камал. || Кемгә, нәрсәгә багышлап, атап. *Халык шаулашып, яратып, кул чабып алды, киявү белән кызга карата мактау сүзләре әйтелде.* А. Шамов. *Әсирләр лагеренда бер иптәшем белән фажигале очрашуга карата язылган бу шигырьне күп әсирләр үзләренең дәфтәрләренә күчереп алганнар иде.* А. Алиш.

4. Яраштырып, юнәлдереп. *Һәрбер проблеманы үзебезнең файдабызга карата чишәбез.* Һ. Такташ. || Ярашлы, муафыйк, бәйләнешле. *Әдип күбесенчә авылның бай һәм хәлле катлавын яза, жанр картиналары да шуңар карата, шуңар муафыйк рәвештә бирелә.* Г. Нигъмәти.

КАРАТУ *ф.* **1.** *йөкл. юн. к.* карау.

2. Юнәлтү, юнәлдерү. *Митричев козырегын артка каратып кигән яшькелт фуражкасын сул колагына этәреп куйды.* Г. Бәширов.

3. Җәлеп иттерү, игътибар иттерү. *Тигезлек нурын җиргә тараттыгыз, Күп халыкны үзегезгә каратгыгыз.* М. Гафури. *Артыкбикә беренче җыры белән үк залны үзенә каратты.* М. Әмир. || Яраттыру, багындыру. [*Кәрим:*] *Бәлки, мин Хафизаны үземә карата алырмын.* Г. Камал.

4. *рәв. мәгъ.* **каратып.** Карата, турында, багышлап. *Син дустыма каратып Җырлар язам яратып.* Җыр. || Яраштырып. *Ул [иптәш] чынлап та „Интернационал“ны үзгәртеп, үзе әйтмешли, хәзерге чорга каратып, бик иркен эшләгән.* М. Җәлил.

КАРА-ТУРЫ *с.* Куе җирән ат төсе. *Бу атлар асылда кара-туры булып та, тирләп чыккан парлары өсләренә бәс булып ябышкач - - - ап-ак булып күренәләр иде.* М. Гафури.

КАРАТУТ *с. к.* кара-тутлы. *Кара чәчле, каратут чырайлы карт кеше иде ул [Бәбенәй абзый].* Ш. Маннур.

КАРА-ТУТЛЫ *с.* Кояшта пешеп каралган яки тумыштан шундый тәнле (кеше турында). *Теге яшь татар белән кара-тутлы кыз скамьяга янәшә утырганнар иде.* Ф. Әмирхан.

КАРАУ I *ф.* **1.** Күзләрне нәрсәгә булса да юнәлтеп (төбәп), күреп, шул нәрсә турында мәгълүмат алу. *Гөлсем апа өстәл арасыннан чыкты да сәгатькә карады.* Д. Аппакова. — *Аска карама син, алга таба кара, йөз чакрымдагы авыллар күренә торгандыр моннан.* И. Гази.

2. Тамаша итү, күзәтү. *Рифгатьнең каравы карау улмады, хәтта нинди фильм күрсәткәнлекләре дә аның хәтерендә калмады.* М. Әмир. *Маратның үзенең дә рәсемле китабы бар. Һәм ул аны теләгәнчә карый ала.* Г. Гобәй.

3. Тикшерү, тикшереп карау. — *Киленкәем, ашның тозын карый күр.* Г. Ибраһимов. || Авыруның яки авыруы бар дип уйланган кешенең хәлен аныклау. *Бер көнне үземне Чылты авылына авыруны карарга алып киттеләр.* Г. Кутуй.

4. Хөкемгә кую, тикшерү, хәл итү. *Дума төрле мәсьәләләрне карар өчен комиссияләр сайлаган. „Урал“. Актыкта партиягә керергә теләгән кешеләрнең гаризаларын карауга чират җитте.* Ш. Камал.

5. Билгеле бер каршта тору, мөнәсәбәттә булу. *Киләчәккә өмет белән карау. Тәнкыйткә кем ничек карый.* □ *Яхшы эшчеләргә крестьяннар начар карамыйлар.* Һ. Такташ. — *Кайбер - - - кешеләрнең миңа ышанмыйча шикләнеп карауларын мин беләм.* Ш. Камал. || Исәпләү, санау. *Ферма эшчеләре Нургалигә үз итеп карыйлар.* Ә. Еники.

6. Тәрбияләү; тиешле хезмәт кую, хезмәт күрсәтү. *Сез күрерсез, шундый матур итеп Ул баланы карар, үстерер.* М. Җәлил. *Хәзер кул астындагы барлык атларны карау, абзарларны чистарту, ком сибү Сабир бабай белән Газинур өстенә төшә.* Г. Әпсәләмов. || Башкару, җаваплылыкны өскә алу. — *Сезнең вазифагыз бер генә, укымак, укымак, тагы укымак, әмма идарә, программа эшләрен мөгаллимнәр карар.* Г. Ибраһимов.

7. Нәрсәне дә булса төзек яки җыйнак хәлдә тоту. *Әхтәм абзый да урта кул балта остасы иде. Ул хәзер Гафинең тегермәннәрен карый башлады.* Ш. Маннур. — *Шулкадәр өлгермим, кот чыккыч! Өйне дә карый алмыйм.* А. Расих. || Хәзерләү (урын-җир, табын-фәлән турында). *Сафия абыстай самовар карарга, чәй урыны хәзерләргә кереште.* А. Шамов.

8. Берәр нәрсәне эшләүне, башкаруны максат итеп, шуның хәстәренә керешү, җаен, мөмкинлекләрен чамалау. *Үз файдамны үзем карамасам, кеше кайгыртмас.* Ш. Мөхәммәдев. *Шуның белән сүзне бетереп, тизрәк үз өенә чыгып китү ягын карады Сәрвәр.* Ф. Хөсни.

9. Табыш бармы икән дип тикшереп чыгу (ау корылмаларын, кош ояларын һ. б.). *Тозак карау.* □ *Күлнең бер як читендәрәк балыкчылар ишкәкләре белән суны шапырдатып, әрле-бирле йөриләр, кичтән салып калдырган нәрәтәләрен карыйлар.* М. Гафури. [*Гайшә:*] *„Бәлки тавыкларым салгандыр, ичмасам, өч-дүрт йомыркадан тәбә ясармын,“, дип уйлап, абзарга оя карарга йөгермәк булды.* Г. Ибраһимов.

10. Билгеле бер якка юнәлгән, юнәлдерелгән булу. *Зиннәт Иделгә караган дүрт өлгеле кечкенә тәрәзә янына килде.* Г. Бәширов. *Аерым үскән агачларның гына төньякка караган тармаклары сирәгрәк һәм кыскарак була.* Г. Әпсәләмов.

11. *күч.* Берәр нәрсәгә мөнәсәбәтле, бәйләнешле булу, шуның составында, эчендә тору. *Поэмада шәхес, табигать һәм тормыш күренешләренә караган нинди сурәтләр бирелгән һәм аларның иҗтимагый урыны нинди?* Г. Нигъмәти.

12. *күч.* Ияртү, үрнәк алу. *Безгә карап Рафаэль дә җырлаган булып кылана.* Г. Кутуй.

13. *күч.* Бер-бер хәлне, факторны күз алдында тоту, исәпкә алу. *Юрганыңа карап аяк суз.* Мәкаль. *Кызхатын ул туганнар сүзенә караучан халык.* Ш. Камал. || *юклык форм.* Берәр хәлгә, сыйфатка, факторга карамастан эш итү. *Картлыгыма карама. Кирәк икән мин бүген дә солдат.* Н. Исәнбәт. *Бураның дулавына, җилнең улавына, бозларның ярылуларына карамыйча, боз лагере эшен дәвам итте.* А. Алиш.

14. *кер. сүз. функ.* **карармын, карарбыз.** Берәр сүзгә, хәбәргә, янауга һ. б. ышанмыйча, үз исәбең белән хөкем йөртүне, үзеңчә эш итүне белдерә. — [*Бурычны*] *бирмим, дисеңме. Ярый, күрербез. Карармын, ничек бирмичә калырсың икән?* К. Тинчурин.

15. *сөйл. рәв. мәгъ.* **карап.** Җентекләп, сайлап. *Товар алсаң карап ал.* Мәкаль. *Шәһәр халкы бигрәк карап, яңа чыккан модный нәрсәне сайлыйдыр.* Ш. Мөхәммәдев.

16. *бәйл. функ.* **карап.** (Кемгә, нәрсәгә) таба юнәлеп, юнәлгән килеш. *Тиешле кирәк-яракларны алгач, өчесе дә, арбага утырып, авылга карап киттеләр.* Г. Минский. || Каршы, таба (вакыт турында).— *Син кичкә карап нишләп йөрисең?* Ф. Бурнаш.

17. *бәйл. функ.* **карап.** Күрә, ярашлы рәвештә. *Үлегенә күрә мазары, товарына карап базары, дигән бабайлар.* Т. Гыйззәт.

18. *бәйл. функ.* **караганда.** Әгәр - - - (билгеле бер рәвештә, шартларда) карасаң. [*Тормыш*] *бер карагандa бик гади кебек.* Г. Нигъмәти. *Мөхәммәтвәли ул өстән карагандa гына юаш.* Ә. Фәйзи. *Тыштан карагандa Шәех бернәрсә дә уйламаган кебек.* М. Гафури.

19. *бәйл. мәгъ.* **караганда.** Буенча, беленгәнчә. *Судның барышына карагандa, эш бик җиңел бетәчәк.* Һ. Такташ. *Малайларның әйтүенә карагандa, ул алма сатучы - - - безнең авылдан чыгып киткән.* Ф. Хөсни.

20. *ы. мәгъ.* **кара.** Шелтәләү, янау, үчекләү, гаҗәпләнү, соклану тойгыларын белдерә. *Явыз хатын, кара, ни дип сөйләнә!* Н. Исәнбәт. *Кара, кара, моның да теле бар икән!* М. Фәйзи. *Кара безнең Шиһапны, хикәя яза башлаган!* М. Җәлил.

21. *ы. мәгъ.* **карасана.** Гаҗәпләнеп игътибар итү төсмерен бирә. *Карасана, зинһар, бу йортның каралыгын!* Г. Камал.

22. *ярд. ф. функ.* Эшнең тәжрибә, сынау сыйфатында башкарылуы төсмерен белдереп килә. *Хәзрәт никадәр догалар укып, тәрилкәләргә өшкереп караса да, файда бирмәде.* Ш. Мөхәммәдев. *Дә бит Мичурин бабай җимеш агачларын ничек кенә үстереп карамаган!* Г. Бәширов. || Боерык формасында янау төсмерен дә белдерә.— *Җибәреп кенә кара,* — *мәйтәм,* — *яучының сөякләрен җыйнарга үзең килмәгәең.* Г. Минский.

Карап үтү (чыгу) — өстән генә укып чыгу, хәтердә яңарту һ. б. өчен актарып чыгу. *Паларусов - - - артель, коммуна, колхоз турындагы кечкенә китапларны бик өстән генә карап үтте.* Г. Ибраһимов.

◇ **Кара(гыз) аны** — янау-кисәтү сүзе. [*Гафиятулла абзый:*] *Карагыз аны, малларны игенгә җибәрә күрмәгез,* — *дип малайларны кат-кат кисәтеп куйды.* Г. Әпсәләмов. **Кара син аны** — берәр нәрсәнең шелтәле яки гажәбрәк, көтелмәгәнрәк ягына игътибар иттерү өчен әйтелә. — *Кара син аны, нинди зур егет булган.* Т. Гыйззәт. **Карагыз әле** — „шуңа да игътибар итегез“ мәгънәсендәге мөрәҗәгать сүзе. *Карагыз әле, Рәшат, сезнең әле генә теге урманга барганыгыз юктыр.* Ф. Әмирхан. **Карар күзгә** — өстән караганда. *Ул карар күзгә утыз-утыз биш яшьләр чамасындагы хатын иде.* А. Шамов.

КАРАУ II *и.* **1.** Каралу, тикшерелү процессы. *Вахитның күңеле тынычсызлана, йөрәге тибә. Бер сәгать вакытны үткәрү аның өчен чиксез озак тоелды, һаман да карау башланмый иде әле.* М. Гафури.

2. *сир. бәйл. функ.* **каравында.** Карамагында, җаваплылыгында. [*Капитан:*] *Мин бүген килгән отрядтан тагын алтмыш кешене Хәмит старшина каравында качкыннарның чигенү юлын кисәр өчен җибәрдем.* Ф. Бурнаш.

КАРАУЛАУ *ф. сөйл. к.* каравыллау. *Көннәр, төннәр, зобаныйлар Тәрәзәмне караулый.* С. Рәмиев. *Боектырып назлы күңелне, Карауладың минем гомерне. Син, авыру, тизрәк кит инде. Синең көнең бетте бит инде.* М. Җәлил.

КАРАУЛЫ *с.* Төзек итеп тотылган, тиешле тәртиптә булган. — *Өйләнәм дисәң, бетекәндер сиңа берәр тол хатын. Тамагың тәрбияле, өстең-башың караулы булыр иде ичмасам.* Р. Төхфәтуллин.

КАРАУСЫЗ *с.* Тәрбиясез, хуҗасыз; каравылсыз, саклаусыз. *Караусыз чебешләрне аңдап йөргән каргалар берничә чебешне тибеп тә өлгергәннәр.* М. Гафури. *Үз гаебебезне тою безне сабырландыра һәм тиктомалга гына җәнҗәл да күтәрәсебез килми иде. Йөкләрне үзебез караусыз калдырдык бит.* А. Гыйләҗев.

КАРАУЧЫ *и.* **1.** Тәрбияче, карап үстерүче. [*Хәзрәт*] *мине күргәч, кайдан килгәнемне, караучым барлыгын-юклыгын сорашты. Мин үземнең ятим малай икәнемне, караучым юклыгын сөйләдем.* М. Гафури. || Хезмәт күрсәтеп торучы кеше, хезмәтче. *Йөгереп килделәр, ди, патшаның караучылары, алып салдылар, ди, алар, Капкорсак патшаны алтын тәхетенә.* А. Алиш. || Берәр нәрсәнең, объектның төзеклеге, җыйнаклыгы өчен җавап бирүче, күзәтеп торучы кеше. *Бакча караучысы.* □ *Ләкин ул гел матур була бик аз вакыт, Караучысыз, ялгыз башы һәлак була.* Ш. Мөдәррис.

2. Күзәтеп карап торучы кеше; тамашачы. *Ш. Камал укучы һәм караучы игътибарын Рәүф һәм Галиягә юнәлдерергә тиеш.* Г. Нигъмәти.

КАРАЧ *и. диал.* Кара төстәге яшь терлек (йорт хайваны). *Бәрән белән минем арада бик зур дуслык башланды. Мин шул карачның хуҗасы булып киттем.* Ф. Әмирхан.

КАРАЧА I *и.* Кечкенә кара нәрсә, тап. *Ары да барыр карача, бире дә килер карача; Тал төбендә тоныk су — тондырып эчәр карача.* Табышмак (борча турында).

КАРАЧА II *с.* **1.** Моржасыз, учак төтене төннектән генә чыгарыла торган (өй, мунча турында). *Болар биш җәяүле, бер атлы булып тагы чыгып киттеләр. Инде тагы бер ай тулганда, юл буенда бер карача гына өйгә туры киләләр.* Әкият.

2. *рәв. мәгъ.* Кара акыл белән, наданнарча. — *Безгә, карача гына уй йөрткән кешеләргә, барсы алим.* Г. Әпсәләмов.

КАРАЧАЙ *и.* Төньяк Кавказда, башлыча Карачай-Черкес автономияле өлкәсендә яшәүче төрки халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. | *с. мәгъ. Карачай теле.*

КАРАЧА'ЙЧА *рәв.* Карачай телендә. *Карачайча сөйләшү.*

КАРАЧКЫ *и.* I. Күбесенчә кеше сурәте рәвешендә ясала торган куркыткыч. *Бакча карачкысы.* □ *Хисам бабай - - - [баганага] аркылы таяк кадап, Иске-москы кидереп, Бик куркыныч иттереп Карачкы ясап куйды.* Ш. Маннур. || *күч.* Бик ямьсез, килешсез кыяфәтле кеше (яки берәр җан иясе). — *Алма кебек кызны бер карачкыга димләр хәлем юк.* М. Фәйзи.

2. *сир.* Кеше яки хайван төсле итеп ясалган фигура, сөкәт. *Иң элек ераkта бер карачкы куеп, һәрберебез шул карачкыга төзәп атабыз. Кемнең угы кардан өеп ясалган шул карачкыга тими үтсә, ул кеше отылган исәпләнә.* М. Гафури.

3. *к.* карачкыл I. *Юлның әле бер ягында, әле икенче ягында күңелгә шом салып торган карачкылар хәзер инде салам өемнәре, печән чүмәләләре - - - ялгыз агачлар булып ачылалар.* И. Салахов.

КАРАЧКЫЛ I *и.* Тышкы сызыклары ачык күренеп тормаган карацгы шәүлә, сурәт, тонык силуэт. *Тирә-якта әллә нинди карачкыллар күренәләр. Барсаң, я берәр*

өем таллык була, яки бернәрсә дә булмый. М. Гафури. *Чү! Тукта! Алда бер карачкыл тора.* Г. Ибраһимов.

КАРАЧКЫЛ II *с.* Күгелҗем-кара, кара-күчкыл. *Күк йөзен карачкыл болытлар каплап ала.* Ә. Айдар. || Бик кара тутлы (кеше йөзе турында). *Чугуновның карачкыл йөзе, шулай ук карачкыл бармакларының хәрәкәте, ялтырап торган кара чәчләре: „Эх син, үзең коммунист“, — диярләр кебек тоелды Хәбибуллинга.* Р. Ильяс.

КАРАЧКЫЛЛАНУ *ф.* Тоныкара төскә керү; карасулану. *Карачкылланып торган суда яшькелт кырлы ак бозлар ага.* А. Расих.

КАРАЧМАН *диал.* Карасу йөзле, карасу тәнле. *Карачмән кыз — кайнар кан, сары кыз — салкын кан.* Мәкаль.

КАРАЧЫ *и. тар.* Ханлык чорында дәүләт аппаратындагы югары чин—диван (ягъни әре феодаллар җыенының) члены. *Акыллы карачы кара җирдән каек йөртер.* Мәкаль. *Акыллы карачы акыллы караны [гади кешене] хан итәр.* Мәкаль.

КАРА-ЧУАР *с.* Кара катыш чуар. *Ала-кола, карачуар бары бетеп, Кызыл байрак кына калыр җир шарында.* М. Гафури.

КАРА-ЧУТЫР *с.* Әре шадралы һәм кара (кеше йөзе турында). *Безнең ярлар карасылу, Сезнеке карачутыр.* Җыр. || Гомумән бик карасу йөзле. *Балаларның кечерәге малай, төсе-бите белән Ифратка тартым кара-чутыр иде, зуррагы исә кыз бала, анасыдай аксыл чәчле, зәңгәр күзле.* А. Расих.

КАРАШ *и.* 1. Карау юнәлеше. *Башка кроватьлардагы яралылар күз карашларын Саттаровка төбәделәр.* А. Шамов. || Күз каравындагы тойгы, хис чагылышы, карау рәвеше. *Бу сүзләрне әйткәндә, Нәсимәнең күзләрендә ачулы караш беткән иде.* Ш. Камал.

2. Аң, уй-фикер. *Иске караш, иске йолалар Яңа кешенең туып үсүенә Киртә булып чыгып торалар.* Һ. Такташ.

3. Чынбарлыкны аңлау, бәяләү; иҗтимагый чынбарлыкка мөнәсәбәт. *Дөньяга караш.* □ *Кешелегең синең һәр кешедә Шундый матур караш калдырды.* З. Мансур. *Эшкә сау караш белән карыйк.* М. Җәлил.

Караш ташлау (төшерү) — тиз генә яки мәгънәле итеп карап алу. *Газинур, тагын да көчлерәк кызарган әлфиягә шаян караш ташлап, Хәнәфигә омтылды.* Г. Әпсәләмов.

КАРАШТЫРУ *ф.* 1. Өстән-өстән генә яки бүленеп, туктап-туктап карау. *Рөстәм Сәгыйдәнең китапларын караштырып утыра.* Һ. Такташ.

2. Тиз-тиз яки әледән-әле карау, күзәтү. *Мин тирәюньне караштырып барам.* И. Гази.

3. Ашыкмыйча гына хәстәрләү, хәзерләү, берәр эш башкару. [*Сирай:*] *Ярый, катын, мин ишек алдын караштырырга чыгам.* М. Фәйзи. — *Парны бетердегез, тирес чыгардыгыз. Инде, кулга балта тотып, йорттагы да бераз караштырырга вакыт.* Р. Төхфәтуллин. || Нәрсәне булса да эзләп (мәсәлән, сатып алу нияте белән һ. б.), булдырырга тырышып йөрү. — *Ат караштырам дисеңме әле син, Хәйбулла дус? Бик шәп, бик шәп.* Ш. Камал.

КАРАШУ *ф.* 1. Бер-береңә карау. *Тәрәзәләрдән карашыйк, Алтын балдак алышыйк.* Җыр. *Габдрахман белән Зариф күзгә күз генә карашып алдылар.* А. Шамов.

2. Кararга, тәрбияләргә ярдәм итү. [*Җәлә:*] *Ата-анасыз, туган-ырусыз тилмереп калган малайны карашып йөрүме, Шәмсәттәй?* М. Фәйзи.

КАРАЮ *ф. диал.* Каралу, кара төскә керү. [*Фатыйманың*] *кара күзләре тагын да карая төшкән кебек булды.* И. Гази. *Өйнең --- түбә такталарына яшел мүк чыккан, бүрәнәләре тәмам караеп беткән.* Ә. Еники. || Керләнү, пычрану. *Безнең өйдә хатын-кыз затыннан бер кеше дә булмаганга күрә, әйберләр тырымтарагай ята башладылар. Идән карайды. Мич тирәсе чүп-чар белән тулды.* М. Гафури.

КАРАЯК *и.* Үсемлекләрнең сабак төбе черү — бактериаль авыру.

КАРАҢГЫ *с.* 1. Яктылыктан мәхрүм, яктылык төшмәгән, төшми торган, якты булмаган, якты түгел. *Караңгы төн. Караңгы бүлмә.* □ *Төн шундый караңгы, күзгә төртсәң дә күренмәслек.* А. Шамов. | *хәб. сүз мәгъ. Караңгы дип килми калма, Ай булмаса, йолдыз бар.* Җыр. || *и. мәгъ.* Караңгылык. *Караңгыга бату. Караңгыда калу.* || *и. мәгъ.* Караңгы чак (вакыт), кич, төн. *Караңгыдан тору.* □ *Караңгыга калгач, карап бардың ни, күзләреңне йомып бардың ни.* Ш. Камал.

2. Төп төскә караганда куерак, каралҗым төсмердәге. *Миңлегәл үзенә бик килешле караңгы зәңгәр күлмәктән, яланбаш.* Р. Төхфәтуллин.

3. *күч.* Надан, мәгърифәтсез, артта калган. *Революция караңгы татар авылындагы егетләрнең дә күзләрен ачты.* И. Гази. *Караңгы катлау мөселман агай-эне аллага ялвара.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Ачык түгел, билгесез, серле. *Кияү ат шикелле — караңгы товар.* Мәкаль. *Белмим, гаеп кемдәдер — аттамы, тәртәдәме? Анысы безгә караңгы.* Г. Бәширов. [*Сания:*] *Тик минем киләчәгем әле ничектер караңгы.* Р. Ишморат.

5. *күч.* Авыр тәэсирле, ямьсез, күңелсез, начар. *Тормышның караңгы күренешләре.* □ *Әй, бабай, бабай, синең бөтен гомерең авыр һәм караңгы тормышта үткән.* Г. Гали. *Кочегар турында да берсеннән-берсе караңгырак сүзләр таралып китте.* Г. Ибраһимов.

◇ **Караңгы күздә (күзле)** — көн яктысы булмаган яки бик начар булган вакыт турында. *Ир-ат караңгы күзле кышкы көннәрдә читкә китеп, сезонлы эшләрдә йөри иде.* С. Рафиков. **Караңгы почмак** — илнең культура үзәкләреннән читтә торган җире. *Олы Россия диңгезендә күтәрелгән куәтле революция дулкыннары да илнең караңгы почмакларында яшәгән халыкларның кайбер караңгы катлауларына баштарак менә шулай булып тоелды.* Г. Ибраһимов. **Караңгы чырай (йөз)** — ризасызлык яки шелтә белдереп торган чырай (йөз). *Инде кызлар дисәң, алар да караңгы чырай күрсәтми төсле.* Г. Бәширов. **Караңгы төшү (иңү, кабу, чүгү)** — караңгы була башлау, кич булу, кич караңгылыгы куеру. *Ул арада кояш баеды, караңгы төште. Көндез шау-шу килеп, кайнап торган шәһәр тынып калды.* Ш. Еникеев. *Тиздән караңгы иңәр.* К. Нәҗми. **(Бер) караңгыдан икенче караңгыга кадәр** — таңнан төнгә кадәр. — *Рус, чуваш, мари, татар батраклары барыбыз да аңа [байга] бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр эшләдек.* Г. Әпсәләмов.

КАРАҢГЫЛАНУ *ф.* 1. Кич булу; караңгы булып китү. *Тирә-як караңгылана башлады.* Г. Коләхметов. *Шәфәкъ батканнан соң, төн дә караңгыланганнан-караңгылана бара иде.* Ш. Мөхәммәдев. | *з-сыз. Караңгылангач, Озын Гайса, ниндидер яшерен эшкә җыенган төсле, капкасын бикләде.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Кәефсезләнү, усаллану, кырыслану (йөз, чырай турында). *Бер ачылды, бер караңгыланды аның [Хафизулланың] чырае.* Г. Минский.

КАРАҢГЫЛАУ I *ф.* 1. Караңгы итү, яктылыгын кимәтү, яктылыкны каплау, яктылык төшермәү. *Бүлмәне караңгылау.* || Якты нәрсәне каплау, күләгәләү. *Күкне болытлар караңгылау.*

2. *күч.* Караңгы (5 мәгъ.) төсмер бирү, каралау. *Шатлыкны куркыныч караңгылады.* Г. Гобәй. *Нәфисә уйлый: сугышчан егетләрнең йөзен икеләнү күләгәсе караңгыламыймы?* Г. Бәширов.

3. *сөйл. з-сыз.* Караңгы төшү, караңгылану. *Әле артык караңгы түгел шул, бераз караңгылансын.* Ш. Камал.

КАРАҢГЫЛАУ II *и.* Сугыш вакытында утка тоту объектларын дошманга белендермәс өчен төнге яктыртуны, утларны каплау, яшерү һ. б. ш. чаралар системасы. *Караңгылау әле һәр йорттa, — Кичләрен ут алмый Минзәлә.* Г. Хуҗи.

КАРАҢГЫЛТ *с. сир. ким. дәр. к.* караңгы. *Караңгылт болыт. Караңгылт су.* □ *Иске авылның Кара күренешләре китми һаман, чыкмый исемнән; Караңгылт бер Кабер төсле булып, Калкып ята хәтер читендә.* Х. Туфан.

КАРАҢГЫЛЫК *и.* **1.** Караңгы булу. *Төннең караңгылыгы.* || Караңгы булу халәте; караңгы чолганыш, караңгы фәза. *Төн караңгылыгы. Кичке караңгылык.* □ *Тирә-якка бердән тоташ караңгылык җәелде.* Г. Минский. *Төпсез галәм караңгылыгында йолдызлар күз кыса.* С. Рафиков.

2. *күч.* Наданлык, культурасызлык. *Иске тормыш караңгылыгында укый-яза белмичә калган кешеләрне өйрәтергә дип җибәргәннәр иде аны [Вафинны].* Ф. Хөсни. *Авыл һаман шул караңгылыгында яши бирә.* Г. Нигъмәти.

3. *күч.* Авырлык, кайгы-хәсрәтле билгесезлек. *Хәйрүшнең тормышын караңгылык басты.* М. Хәсәнов. || Явызлык; реакционлык. *Тар-мар итеп коллык, караңгылык Саклап яткан дошман оясын, Каны белән халкым саклап калды Кешелекнең якты кояшын.* М. Җәлил.

◇ **Караңгылык кабу** — караңгы тәмам төшеп бетү, караңгылану. *Әмма каравыл кычкырып булмый, көнгә караңгылык капканчы ничек тә чыдарга кирәк иде [Гайфулга].* Ф. Хөсни. **Караңгылык куеру** — караңгылана бару. *Караңгылык куера башлап, тырма әзләре күренмәс булганнан соң, Гөлсем тракторның фараларын яктыртып җибәрде.* Г. Бәширов.

КАРАҢГЫЛЫ-ЯКТЫЛЫ *с.* **1.** Ярым караңгы яки бер өлеше генә яктыртылган. *Әллә нинди караңгылы-яктылы бүлмәдә бик әкрен, бик көчкә генә сөйләшәләр, сүзләре аңлашылмый.* Ш. Камал.

2. *и. мәгъ.* Иртәнге ярым караңгы чак; таң вакыты. *Әгъләм аннан-моннан гына капкалап, караңгылы-яктылыда ук чыгып киттe.* Ф. Хөсни.

КАРБАМИД *и.* Углерод (карбон) кислотасының аммиаклы тозы — төссез кристалл, кәнкүрештә һәм авыл хуҗалыгында кулланыла. *Терлекләргә арзанлы, аксымга мул, биологик яктан рациональ булган тукланыклы меню хәзерләү өчен нибары - - - карбамид дип атала торган азотка бай матдә генә кирәк икән.* М. Хәсәнов.

КАРБИД *и. махс.* Металларның углерод (карбон) белән кушылмасы. *Калий карбиды. Натрий карбиды.*

Карбид лампасы — *к.* **карбидка.** *Карбид лампасы белән яктырту.*

КАРБИ'ДКА *и.* Ягулык сыйфатында кальций карбиды һәм су кулланыла торган махсус лампа. *Карбидка яктылыгы астында штольня эчендә төн белән көнне аерып булмый.* Э. Айдар.

КАРБИКӘ *и. миф.* Кардан яралган яшь кыз, кар кызы. *Карбикә ярсып, язга ашкынды, Ул гашыйк булды көчле кояшка.* М. Җәлил.

КАРБИЯ *и.* Вак алабута. *Сарут, кычыткан, балтырган, песи тарысы һәм карбия үләне туфракта азот күп булуны күрсәтүче үсемлекләр.* Робинзон әзл.

КАРБО'Л: карбол кислотасы. Дезинфекция өчен кулланыла торган фенол.

КАРБО'ЛКА *и. к.* **карбол кислотасы.** *Карболка белән дезинфекцияләү.*

КАРБОН *и.* **1.** *хим. иск.* Углерод. *Карбон оксиды.* **2.** *махс.* Борынгы бер геологик эпоха. *Борау һаман аска төште. Менә карбон-күмер туган чорлар. Ерак калды җирнең өсте.* Ш. Маннур.

КАРБОНАТ *и.* Углерод кислотасының тозы. *Туфракка карбонатлар кертү.*

КАРБЫЗ *и.* Кабаксыманнар семьялыгыннан үрмәле үсемлек. *Карбыз басуы.* || Шул үсемлекнең татлы эчле шар сыман зур җимеше. *Нинди генә карбыз әле: пычак тимәс борын ярылып китә, борыныңа хуш исе килеп бәрелә, авызың тисә аерыла алмыйсың.* Г. Бәширов.

◇ **Карбыз кабыгы ташлау** — хәйлә-мәкерләр белән комачау тудыру, аяк чалу, кешенең абруен төшерергә тырышу. *„Кешесен тапкан инде", дип мыскыллап та куя. Шулай итеп, Тимер очраган бер урында Фәхинең астына карбыз кабыгы ташлый иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КАРБЫЗЧЫ *и.* **1.** Карбыз үстерүче, карбыз игүче. *Карбызчылар звеносы.*

2. Карбыз белән сату итүче. *Карбызчылар, алмачылар яныннан да егетне [Хәлимне] бик тиз өфертеләр. Кайсы гына кибет каршына барып туктамасын: „дй, шалама, сыпырт моннан!" — дип кычкыралар.* И. Гази.

КАРБЮРА'ТОР *и.* Эчке янулы двигательләрдә янучан кушылма ясала торган прибор. *Өлкән трактурчы, люкны ачып, шатун болтларын, һавачистарткыч белән карбюраторны тоташтырган шлангларны тикшерде.* Ф. Хөсни.

КАРГА *и.* **1.** Козгыннар семьялыгыннан елтыр кара яки шәмәхә-кара каурыйлы урта зурлыктагы кош. *Карга килсә, кар китәр.* Мәкаль.

2. *күч.* Башкалар җилкәсендә яшәүче кеше, әрсез паразит. *Ил өстендә илле карга.* Мәкаль. *Монда Мифтах мулла дигән бер карга бар.* Һ. Такташ. || Гомумән, тиешсезгә нәфес сузучы кеше. *Бер чибәррәк кыз булса, аңа күз салган әллә ничаклы каргалар буладыр.* М. Гафури.

3. *күч.* Почмак рәвешендә сызылган билге яки тамга. *Ифрат мәсьәләне хәл итеп, кайбер паспортларга тәре билгесе, кайберсенә „карга" тамгасы салды.* А. Расих.

4. *күч. жар.* Уен картасы (кәрт) билгеләренең берсе; *русчасы:* пики. *Карга короле.*

Карга борчагы (кузагы) — *к.* кырлы борчак (чина). *Җир башларын, юл буйларын, уем-уем чи урыннарны, тоташ-тоташ кишәрлекләрне әрем, алабута, карга борчагы, тигәнәк, сарут басып китә.* Р. Төхфәтуллин. **Карга борыны (күзе)** — пасленчалар семьялыгыннан вак-вак кара җимешле үлән; *русчасы:* паслен черный. *Яшел таплы җир өстендә күгәргән, мүкләнгән нигез ташлары арасыннан юан сабаклы алабуталар, карга борыннары, сукыр кычытканнар котырып үсеп чыккан.* А. Гыйләҗев. *Карга күзенең бер-берсенә аркылы-торкылы торып үскән эре-эре дүрт яфрагы һәм уртада карга күзе шикелле кап-кара җиләге була.* Робинзон әзл. **Карга бураны** — кара каргалар килер алдыннан була торган язгы буран, март бураны. *Карга бураннары да шаулап үтәр; елгалар ярларыннан ташып чыгар.* И. Гази. **Карга боткасы** — яз ахырларында бала-чага, яшь-җилкенчәк кырга, болынга җыйнаулашып чыгып пешерә торган аш, ботка. *Яз көне карга боткасына чыгу.* **Карга кары** — эре, авыр бөртекле җепшек язгы кар. *Һаваның салкынлыгына карамастан, карга кары - - - өзлексез явып тора.* К. Тинчурин. **Карга миләше** — кара яки кызыл төсле ваграк җимешләре булган куак үсемлек; *русчасы:* бузина. *Карга миләше әфлисун эче кебек кызгылтсары төскә керде; канәфер, зирек куаклары һаман яшь әле.* Г. Гобәй. **Карга сөяк** — кошларга хас булган

яссы сөяк, киль. *Урдәкборынның кулбаш поясында карга сөяк бар.* Зоология.

◇ **Карга мие эчкән** — башсыз һәм хәтерсез булу. *Юк, булмас инде, булмас андый этләр. Эх, чүбек баш, әх, карга мие эчкән нәрсә.* Ш. Еникеев. **Карга җимгә төшмәс борын** — бик иртә, таң тиштегеннән. *— Карга җимгә төшмәс борын, кая болай кузгалдың, Шәйхи абзый?* М. Хәсәнов. **Карга канаты кебек** — кап-кара, шәмәхә төсмерле һәм бераз ялтыраулы кара. *Илдарның башында кечкенә козыреклы кепка булыр, читеннән карга канаты кебек җете кара чәче чыгып тора.* Г. Гобәй.

КАРГАБОРЫН *и.* Очлы келәшчә. *Каргаборын белән карга борыны бер-береннән бик ачык аерылалар. Болардан беренчесе карга борынына охшаган коралны, икенчесе карганың үз борынын, ягъни томшыгын аңлата.* Л. Җәләй.

КАРГАЛГАН: каргалган ил — җимерелгән, хәрабә хәленә килгән, котсызланган җир, як, ил. *Дәдә, бу каргалган илдән Без сәгадәткә таба Юл салыйк.* Һ. Такташ.

КАРГАНУ *ф.* 1. Каргап-сүгеп сөйләнү, сукрану; кемнедер, нәрсәнедер каһәрләү, ләгънәтләү. *— Йөз түбән килгерләре, — дип карганды карт-коры.* Ә. Фәйзи. *Карганам мин, сукранам мин, Гел язмыш миңа кире.* М. Җәлил.

2. Бик каты ант итү; аһ орып ышандырырга тырышу. *Карга каргылдап, карак карганып котылыр.* Мәкаль. *— Ант итеп әйтәм, мин бу кувшин эчендә идем. — Карганма да. Мин барыбер ышанмыйм.* Мең дә бер кичә.

КАРГАУ *ф.* Берәрсенә яки берәр нәрсәгә карата начар теләк теләү; ачынып рәнҗү. *Карт: — Йа хода, сабыйларны ач калдырып, дөнья корытып йөрүче бу явыз бәндәләреңнең аяк-куллары тартышса ие, — дип каргарга кереште.* И. Гази. *Бу усал карчыктан кайберәүләр бик курка — каргамагае.* И. Туктар.

КАРГАУЛЫ *с.* Каргау сүзләре яки каргау тоны белән әйтелгән. *Хафиза әрнүле, каргаулы тавыш белән каенанасына ташлана: — Карт башың белән юкны чәйнәп торма, әнкәй.* Г. Ибраһимов.

КАРГЫ *и.* Карчыганың кечерәк гәүдәле бер төре. *Каргы — карчыганың азгыны.* Мәкаль.

КАРГЫЛДАУ *ф.* Каркылдауга охшаган, ләкин кискен яңгыравыклы булмаган аваз чыгару (карга, козгын һ. б. турында). *Сузынкы итеп каргылдап кую.* □ *Берәр юлбасар иптәше аның [гитлерчының] бәхет сарае өстенә, козгын кунып каргылдар өчен, усактан ясалган тәре кагып куяр.* Ф. Кәрим.

КАРГЫЛТ *с. диал.* Карага тартым, каралҗым. *Аның [Аляның] шулай сихерле елмая торган, киңчәрәк, каргылт йөзе, бу көнге язгы төн шикелле --- нурлы.* Ф. Әмирхан.

КАРГЫШ *и.* Бик ачулы, үчле теләк; ләгънәт, каргау сүзе. *Сөйгәнгә алкыш, сөймәгәнгә каргыш.* Мәкаль. *Каргышыңа каргышым.* Мәкаль. *Эчем тулы каргыш, үпкә белән Китәм инде җирнең өстеннән; дни мәрхүм мине юкка гына Күз нурларын түгеп үстергән.* М. Җәлил.

Каргыш алу — берәр начарлык, әхлаксызлык эшләп, каргалуга дучар булу. *Кәбир үзе кыйнады, үзе сүгенде: — Мондагы муллалардан гына каргыш алуың җитмәгән, Казанга барып Казан муллаларыннан да каргатасың килә икән!* Ф. Хөсни. **Каргыш төшү** — каргыш теләге үтәлү, каргыш нәтиҗәсе булараk, берәр бәлагә дучар булу (ырымга, юрауга ышану буенча). *Әт каргышы бүрегә төшмәс, сычкан каргышы мәчегә төшмәс.* Мәкаль. *Машиналар бик күп икән Берлин дигән калада; Кем каргышы төште икән Без бәхетсез балага.* Җыр.

КАРГЫШ-ЛӘГЪНӘТ *җый. и.* Төрле каргышлы һәм ләгънәтле сүзләр, теләкләр. *Безнең изүчеләргә каргышлагънәт яудырам.* А. Алиш.

КАРГЫШЛЫ *с.* Каргыш төшкән, каргалган. *— Бөтен бәла синең башыңа ябырыла, Борис. Син, мөгаен, каргышлы сәгатьтә тугансыңдыр!* Г. Ахунов.

КАРДИНАЛ *и.* 1. Католикларда пападан кала иң югары рухани дәрәҗә һәм шул дәрәҗәдәге кеше. *Картлач кардиналлар, епископлар, Экзархлар, поплар тезелеп, СССРга лагънәт яудыралар, Тәреле киемнәргә төренеп.* М. Гафури.

2. Төньяк һәм Көньяк Америкада яши торган кызыл каурыйлы кош.

КАРДИО- кушма сүзләр составында һәм кайбер махсус терминнарда „йөрәк“ мәгънәсендәге сүз, мәсәлән: **кардиосклеро́з, кардиогра́мма, кардиоло́гия.**

КАРДӘШ *и.* 1. Уртак ата-ана яки әби-баба буенча нәсел, туган кешеләр. *Кызларның берсе --- Гөлләр исемлесе, Гафиятулла бабайның ерак кардәше.* Г. Әпсәләмов. || Иптәш, дус, тугандаш. *Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга, Дидем:— Кардәш, бу көй—нинди көй? Җавабында милләттәшем миңа: — Бу көй була, — диде, — „Әллүки“.* Г. Тукай.

2. Аерым тезмәләр составында: уртак сыйфатлар, интереслар буенча якын, үз кеше. *Сыйнфый кардәш. Милли кардәш.* □ *Җан кардәше — мал кардәше түгелдер.* Ш. Камал.

КАРДӘШ-КАБИЛӘ *җый. и.* Нәсел-нәсәп, кардәшлыру. [*Исмәгыйльнең*] *кардәш-кабиләсе бармы? Туган-тумачасы бармы?* К. Тинчурин. *Әлеге эш турысында уйлаштык, сөйләштек, күрше-күлән дигәндәй, кардәш-кабилә белән дә мәслихәтләштек.* Ш. Камал.

КАРДӘШ-КАЛӘМ *и. иск.* Карандаш. [*Гәүһәр туташ*] *ридикюлен ачты, нечкә күк кардәш-каләм белән блокнотын тартып чыгарды.* Г. Ибраһимов.

КАРДӘШЛЕК *и.* 1. Кардәш булу хәле, сыйфаты. *Габдулланы яхшы каршы алдылар. Бу каршылауда, ни әйтсәң дә, кардәшлек җылылыгы сизелеп торды.* Ә. Фәйзи. [*Фәтхинең*] *Мәдинәгә бераз кардәшлеге дә бар бугай, — диде Каюм.* Ш. Камал.

2. Кардәшләрчә мөнәсәбәт; үзара туганлык, дуслык. *Ирек, кардәшлек юлында һәр кеше булсын игез.* Г. Камал. *Гадәләт, туганлык, кардәшлек, закон һәм тәртип яклы кешеләр безнең исемлеккә тавыш бирсен!* Ш. Маннур.

КАРДӘШЛӘ'РЧӘ *рәв.* Кардәшләргә хас булганча. *Кардәшләрчә ярдәм күрсәтү.*

КАРДӘШЛӘШҮ *ф.* Кардәшлек, туганлык, кодалык мөнәсәбәтләренә керү. *Якын белән ярдәмләш, ят белән кардәшлә! Мәкаль.*

КАРДӘШ-ЫРУ, КАРДӘШ-ЫРУГ *җый. и.* Кардәш, нәсел һәм дус-иш, ыругдаш кешеләр. *Малай-салай, кодалар каршы алырга дигән булып, җыела да башладылар. Бала-чага артыннан кардәш-ырулар, күрше-күләннәр агылдылар.* Г. Ибраһимов. *Соңгы берике ел эчендә муллага килгән кардәш-ыруглар бу кыздан күзләрен алмыйлар.* С. Рафиков.

КАРЕ *и. иск.* Озынлык үлчәме — ун басма, ярты тырма (ике аршын = 1,42 *м* чамасында). *Бер каре озынлыктагы килән.*

КАРЕЛ *и.* Башлыча, Карелиядә яши торган угро-фин телле халык һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *— Безнең карел халкының шундый бер гадәте бар: кеше үләр алдыннан үзенең иң яхшы киемнәрен кия.* Г. Әпсәләмов. | *с. мәгъ. Карел теле. Карел эпосы.*

КАРЕНДӘШ *и. иск. диал.* Кардәш, туган. *Бу әфәнделәрнең тук йөзләренә карагач: „Бик күп карендәшләрегезнең нәкъ шушы вакытта ачлык вә сусызлыкта икәнлекләрен оныттыгызмы әллә?“ — дип сорыйсы килә.* Ф. Әмирхан.

КАРЕНДӘШЛЕК *и. иск.* Кардәшлек; үзара дуслык, туганлык. *Керештем мин мәхәббәткә, карендәшлеккә өндәргә.* Г. Тукай.

КАРЕ'ТА *и.* Дүрт тәгәрмәчле, зур көймәле арба (экипаж). *Атлар белән генә хәрәкәткә китерелеп йөртелә торган кара карета әкрен генә икенче җиргә барып туктады.* М. Гафури.

КАРЕ'ТНИК *и. иск. сөйл.* Арба-чана саклана торган махсус каралты. *Кучер Галиуллa капкадан кереп, каретникка таба китте.* Ш. Мөхәммәдев. *Кармак [кушаматлы кеше] әлекке йорт хуҗасының каретнигын утын сараена әйләндереп, шунда үзенә мастерской кебек бернәрсә корып җибәргән иде.* Ш. Еникеев.

КАРИ *и. иск.* Мәчеттә һәм дини мәҗлесләрдә яттан корьән укучы кеше. *Салихҗан кари Россиядәге кариларның кыйраәтләре дөрес түгеллек хакында сөйләп йөрде.* Ф. Әмирхан. *Баязит кари --- матур моң, көчле күкрәк тавышы белән көйләп мәчеттә корьән укый.* Г. Ибраһимов.

КАРИКАТУ'РА *и.* **1.** Кемне булса да мәсхәрәләп, көлкеле итеп төшерелгән сурәт, рәсем. *Шуннан соң безнең әлеге үткен күзле художникгыбыз --- бик шәп карикатура ясады.* Ф. Хөсни. || Шул характерда ижат ителгән башка төр сәнгать әсәре. *Сюитаның икенче булегендә безгә Ключарев авылдагы яшьләр җыенын бирә. Шул ук вакытта автор бик оста гына музыкаль карикатуралар эшләп керткән.* М. Җәлил.

2. *күч.* Берәр чын, реаль нәрсәгә охшатырга тырышып та бик кимчелекле, көлкеле килеп чыккан предмет, күренеш. — *Кинодагы сабантуе сабантуй түгел ул, мәсхәрә ул, карикатура.* Г. Ахунов.

КАРИКАТУРАЛАШТЫРУ *ф.* Тискәре, кире сыйфатларны аеруча көлкеле һәм калку итеп тасвирлау. *Образны үтәдән-үтә карикатуралаштыру үзе үк инде мыскыллау, көлү.* З. Мәҗитов.

КАРИКАТУ'РАЧЫ *и.* Карикатуралар төшерүче художник, рәссам. *Мәктәпнең стена газетасын гаҗәп кызыклы карикатуралар белән чыгаручы карикатурачы-художник Тихвинов --- иде.* С. Баттал.

КАРИКАТУРАЧЫЛЫК *и.* **1.** Карикатуралар төшерү шөгыле, гадәте, эше. *Татарда карикатурачылык эшен башлап җибәрүче — Галиәсгар Камал.* М. Гали.

2. *күч.* Сәнгатьтә карикатуралаштыру күренеше. *Сатирада --- бер нәрсә күзгә ташлана — образны сурәтләүдә карикатурачылык.* З. Мәҗитов.

КАРИЛЫК *и.* Кари булу, кари һөнәре һәм кәсебе. *Баязит күп газаплар эчендә елны үткәрә дә, рамазан якынлаша башлагач, тагы шул карилык белән эш итәргә исәп кора.* Г. Ибраһимов.

КАРИП *рәв. иск.* Якын торган, якынлашкан. *Бу елда кузгалдылар мөселманнар, Үләргә карип булган гарип җаннар.* М. Гафури. || Якынча, чамасында. *Өч йөз меңгә карип сума калган булырга кирәк.* Ш. Мөхәммәдев.

КАРИЭ *и. иск. кит.* Китапны, әсәрне укучы. *Аз гына сабыр ит әле, әй кариэм, хәзер язам.* Г. Тукай. *Кариэ әфәнделәрем, сезне әүвәл Бурангол Исламгулов илә таныштырып, соңра хикәямезгә [күчәбез].* З. Һади.

КАРКАС *и.* Бина яки корылманың төп кысасы — төп авырлыкны күтәреп торучы баганалар, өрлекләр, атламалар системасы. *Галия вышканың дерелдәп торган каркасларына карап алды.* М. Хәсәнов. *Сул якта әле корылып бетмәгән дүрт-биш өйнең каркаслары челтәрләнә.* И. Салахов.

КАРКЫЛДАВЫК *с.* Күп каркылдый торган (карга, козгын).

Каркылдавык карга — кирәкмәгән һәм ямьсез сүзләр сөйли торган кеше турында.

КАРКЫЛДАУ *ф.* **1.** Кар-кар итү, кар-кар кычкыру. *Кошлардан чыпчык яисә сыерчыклар гына чырылдашкалап үтәләр, яисә ала карга ачы тавыш белән каркылдап куя.* Ш. Камал. *Ялгыз карга --- аратирә тамак төбе белән каркылдап, зарланып ала.* Г. Мөхәммәтшин.

2. *күч.* Кирәкмәгәндә һәм бик ямьсез итеп берәр сүз сөйләү; тиешсезгә тавыш күтәрү. — *Белсәң, менә шул: килен өенә килеп, синең кулыңнан барлык ачкычларны алмый торып каркылдама, яме.* Г. Ахунов.

КАРКЫЛДЫК *гади. с. к.* каркылдавык. || *и. мәгъ.* Карга, козгын һ. б.

КАРЛАНУ *ф.* Кар белән капланy; карга буялу. *Бар җир карланган, Сулар бозланган, Уйный җил-буран.* Г. Тукай. *Карларын тазарткач, карланып-бозланып каткан капка шыгырдап ачылып китә.* М. Гали.

КАРЛАУ *и. диал.* Кечкенә көрәк; зур калак. *Әнә карлау, әти аның белән атларга [башак] болгата.* К. Латыйпов.

КА'РЛИК *и. сөйл.* Кәрлә кеше. *Сукыр һәм чукрак батырны карлик та җиңә.* Г. Әпсәләмов. || *күч.* Вак, көчсез кеше. — *Ләкин синең кебек генийларны да мескен карликка, аяк астындагы чүпкә әйләндерерлек көчнең барлыгына ышанмый идем мин.* Г. Иделле.

КАРЛЫ *с.* **1.** Кары булган, карга буялган, кар каплаган. *Карлы тау.* □ *Карлы чәчләр сиңа килешә, Алсу!* Һ. Такташ. *Әни мескен, мине исергән дип уйлап, башыма карлы чүпрәк китереп куйды.* А. Шамов.

2. Кар явып торган. *Әллә нинди карлы, яңгырлы, болытлы көннәр килә.* Г. Ибраһимов.

КАРЛЫ-БОЗЛЫ *с.* Кар белән боз катыш; кар катыш бозлы яки боз катыш карлы. *Фронтта йөргәндә, карлы-бозлы яңгыр астында, озын төннәрне винтовка тотып үткәргән вакытлар күп булды.* М. Гафури.

КАРЛЫ-БУРАНЛЫ *с.* Кар яуган һәм буран бураган; кар явып, буранлап торган. *Яңгырлы-болытлы көз, аның артыннан карлы-буранлы каты кыш үткән.* Г. Ибраһимов.

КАРЛЫГАН *и.* Бакчаларда да, кыргый хәлендә дә үсә торган куак үсемлек. *Үзебезнең Степанга барам да кара карлыган, кызыл карлыган, кура җиләк куагы алып кайтам; читән буйларына утыртам.* И. Гази. *Чем-кара җимешләрен ялтыратып, нигәдер гаҗәпләнгәндәй, карлыган куаклары карап тора.* Г. Бәширов. || Шул куакның кара, кызыл һәм башка төсләрдәге әчкелтем сусыл җимешләре. *Кара карлыганны витаминнарга ифрат бай диләр.* Э. Касыймов.

КАРЛЫГАНЛАНУ *ф.* Карлыган җимеше ясала, йомарлана башлау. *Карлыган карлыганланды микән, карлыганланмады микән?* Тизәйткеч.

КАРЛЫГАНЛЫК *и.* Кыргый карлыган куаклары күпләп үскән урын. *Мин шулай тоpактагы бүлмәмә кайтмадым, яр астындагы карлыганлыклар арасына кайттым.* И. Салахов.

КАРЛЫГАЧ *и.* Чыпчыксыманнар отрядыннан бик җитез оча торган, аксыл түшле, кара канатлы кош. *Өйнең башында, кыек очында, һәр яз карлыгач оя ясый, бала чыгара.* Г. Ибраһимов, *Карлыгачкай кара, муены ала, һаваларга менеп югала.* Җыр. **Карлыгач койрык(лы)** *сөйл.* — астан икегә аерылып торган арт чабу(лы). *Кәбир әфәнде, карлыгач койрыклы фрак өстеннән яшелле-кызыллы, буй-буй чапанны җилбәгәйгә җибәреп киеп алган.* Ә. Фәйзи. **Карлыгач мыек** — кыйгачландырып кырылган көяз кара мыек. *Үлчәүдә эшләүче карлыгач мыек Шәмәрдән абзый... әле ир уртасына да җитмәгән бер кеше.* Ф. Хөсни.

КАРЛЫГУ *ф.* Кешенең гадәти тавышына ят авазлар кушылу, тавыш бозылу. *Таң атканчы, тамагы тәмам карлыгып беткәнче җырлау да Сафага йөкләтелгән.* К. Нәҗми. *Карт полковник, карлыккан тавыш белән кычкырып, гаскәриләргә команда бирде.* Ш. Камал.

КАРМАВЫЧ *и.* Кайбер түбән төзелешле хайваннарның (бөҗәкләрнең, кыслаларның һ. б.) кармау-капшау һәм тотып алу хезмәтен үти торган алгы әгъзасы. *Гидраның авыз ачыклыгы тирәли кармавычлар үскән, кармавычлар ярдәмендә гидра бик вак су хайваннарын һәм башка корбаннарын эләктерә.* Үтк. зам. сәяхәт. *Әкәм-төкәмнең башында бер пар кыска һәм бер пар озын кармавычлар була.* Зоология. || *тех.* Шуңа охшашлы деталь. *Әкиятләрдәге коточкыч зур кыслага охшаган тали блогы, кармавычлары белән эләктереп, торбаның аргы башын югары күтәрде.* Г. Ахунов.

КАРМАК *и.* **1.** Нечкә тимер чыбык кисәгеннән бер очы ыргак сыман итеп бөгелгән балык тоту коралы. *Малайның бер кулында кавырсын, икенчесендә җепкә тагылган ике кармак күренә.* Г. Ибраһимов. || Озын саптан һәм шуңа беркетелгән кармаклы озын җептән гыйбарәт булган балык тоту коралы. *Өй түбәсеннән абыйның зур кармагын алып төштем. Ике шырпы кабы суалчан җыйдым да Ыкка киттем.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Тимер ыргак, эләктергеч. *Дәү, биек кранның угы очындагы трос кармаклары, җилдә тибрәнеп, буш килеш һава сөзәләр.* А. Гыйләҗев. *Бөти тауның башына менеп булмый кармаксыз.* Җыр.

Кармак сабы — кармаклы җеп беркетелә торган озын чыбык. *Кармак сабын кисеп колгадай, Бер урамда үсте биш малай.* Г. Афзал.

◇ **Кармак салу** — берәр файда һ. б. өмет итеп, берәр хәйләгә керешү. **Кармакка кабу, эләгү (каптыру, эләктерү)** — берәр төрле хәйлә-мәкергә алдану (алдату). *Колак торырлык сүз ычкындырып, тыңлаучыларны кармакка эләктергәч, Шапырай карт хикәясен өзә.* М. Хәсәнов. **Кармакка төшерү** — хәйлә-мәкер белән кемне дә булса үз ихтыярыңа буйсындыру яки кемгә, нәрсәгә булса да ия булу. — *Сиңа ышаныч юк, Сабирҗан абзый, берәр тол хатынны кармакка төшерергә чамалап йөри торгансыңдыр.* Ф. Хөсни.

КАРМАКЧЫ *и.* Кармак белән балык тотучы. *Мин үзем гап-гади кармакчы. Утырам шунда яр буенда. Тотканым, иң шәп дигәндә, бер уха пешерергә җитә.* Э. Касыймов.

КАРМАЛАНУ *ф.* Кул белән капшап эзләнү. *Вафин өйгә ут та алып тормыйча, кармаланып кына әйберләрен эзләп тапты.* Ф. Хөсни. *Кармаланып өйгә кердем. Борынга, әче катык исеме, әчкелтем-төчкелтем бер ис бәрелде.* А. Гыйләҗев.

КАРМАЛАУ *ф.* Озак һәм дикъкать белән капшау, кармау. [*Илкә*] *Кесәсен кармалап чак тапты анда бер асыл ташны.* М. Гафури.

КАРМАНУ *ф. к.* кармалану. *Ул [мәче башлы ябалак] яшь каеннар өстендә карманып уралды да куаклыкка кереп посты.* И. Салахов.

КАРМАУ *ф.* Тоткалап карау, капшау. *Мескен Шәрык --- Кулларын җәйгән дә, кармап, нәрсәдер эзләп бага.* М. Гафури.

КАРМИН *и.* Җете кызыл буяу төре. *Карминны кызыл төстәге йонлач үлән бетеннән ала торган булганнар.* Робинзон эзл.

КАРНАВАЛ *и.* Паркларда, урман-кырларда үткәрелә торган маскарадлы бәйрәм җыены. *Якты-Күл җәйләве таң иртәдән шәрыкъның базары, гарепнең карнавалы, гарәпнең мәхшәр дигәне кебек кайный башлады.* Г. Ибраһимов.

КАРНАЙ *и. этн.* Тавышы бик ераккa ишетелә торган озын җиз быргы. *Бу сазларны, кифарларны, флейталарны, тыйбелләрне, быргыларны, карнайларны, курайларны, нәкъкарларны, гөсләләрне --- Лобачевский һәрвакыт бик рәхәтләнеп күздән кичерә.* Ж. Тәрҗеманов.

КАРНАША *и. диал.* Кабыктан, юкәдән үрелгән кәрзин сыман җиңел кызау, тубал. *Мин дә, елга кыргыенарак барып, зур-зур яфраклы үләннәрне бер кулым белән күтәреп, икенче кулым белән җиләкләрне карнашама салгаларга тотындым.* М. Гали.

КАРНИЗ *и. к.* кәрниз. *Кыш буе туңып, бөрешеп йөргән сәләмә чыпчыкларга җан керде: өер-өер җыелышып, шәрә агач ботакларында, тиреслекләрдә, кояш төшә торган өй карнизларында чыр-чу килергә тотындылар.* И. Гази.

КАРОТАЖ *и.* Бур тишеп үткән скважинадагы геологик токымнарны геофизик яктан тикшерү. *Өч тәүлек буе скважиналарда каротаж ясап йөргәннән соң, рәттән ике көн ял алдым.* Э. Касыймов.

КАРОТАЖЧЫ *и.* Җир асты токымнарын скважина ярдәмендә тикшерүче. *Сәгать нәкъ ун тулганда каротажчыларның ике машинасы буровой янына килеп туктады.* Г. Ахунов.

КАРОТИН *и.* Кишердә, йомырка сарысында һ. б. була торган поливитаминлы сары пигмент (башлыча А витаминыннан тора).

КАРП *и.* Төче суларда яши торган каралҗым-алтын сыман тәңкәле сөякчел балык — сазанның бер төре. *Карп үрчетү.* □ *Кар астында күлләр. Ул күлләрдә йоклый карплар.* С. Хәким.

КАРПЫЧ *и.* Терлек ашый алмый торган каты сабаклы үлән.

КАРР, КАР *аваз иәр.* Карга, козгын кебек кошлар чыгара торган кискен, яңгыравыклы авазны белдерә. *Карр итү.* □ *Су буендагы талларга кунып йоклаган каргалар, кар-кар кычкырып, берсен-берсе уяталар.* Г. Гобәй.

КАРСАК I *с.* Кыска буйлы һәм юантык; кыска аяклы (кеше һәм хайваннар турында). *Мәйдан уртасында башларына зур-зур каракүл бүрекләр кигән юан, нечкә, озын, карсак кешеләр авыл агай-эненәреннән тире-яры сатулыйлар.* К. Тинчурин. *Минем Сарбай ул карсак, кыска аяклы.* Г. Лотфи. || Тәбәнәк (каралты-кура һ. б. турында). *Эчпошыргыч шомлы тынлык басты Тирәдәге карсак өйләрне.* М. Җәлил.

КАРСАК II *и.* Төлкеләрнең далаларда яши торган бер төре. *Мин бер арык бурзаймын, җилеп йөргән, Куян, карсак, төлке әзен сизеп йөргән.* Акмулла.

КАРТ *с.* **1.** Озак яшәгән, олы яшьтәге; *киресе*: яшь. *Карт кеше. Карт сыер.* □ *Кышкы кичтә утлар яна җылы өйдә, Онытына әкият сөйли карт әби дә.* Г. Тукай.

2. Бик күптәннән үсеп утыра торган. *Карт агачлар, хәтерлимсез, мин яшь чакта Азмы сезнең янда йокладым?* Һ. Такташ. || Күптән яшәп килгән (җансыз әйберләр турында). *Карт завод ул — яше ике йөзгә Якынлашкан.* М. Гафури.

3. Күпне кичергән; озак эшләгән; тәжрибәле. *Шәһәрне саклаучы армия штабында карт большевиклар план сызалар.* К. Нәҗми.

4. *и. мәгъ.* Олы яшьтәге ир кеше. *Җиһанша бабай — тирә-якта яхшылык белән танылган бер карт.* Г. Нигъмәти. *Дә капка төбенә куелган урак машинасы --- янында зур ак сакаллы, кәләпүшле татар карты утыра.* Г. Ибраһимов. || Олы яшьтәге ир кешенең исеменә өстәлеп әйтелә торган сүз. *Айтуган карт, чал башын селки-селки, Нәфисәнең иңбашыннан сөйде.* Г. Бәширов.

5. *сөйл.* Олы яшьтәге хатыннарның үз ирләренә әндәшү һәм аларны атау сүзе. *Кем йөрер икән? — диде Сафия абыстай, картына җавап итеп. — Кем булсын, Сәйфулладыр әле.* А. Шамов.

Карт кыз — вакытында кияүгә чыга алмый калган, сазаган кыз. *Госманның икенче ягындагы кыз — егерме-утыз яшьләрендәге карт кыз Сара иде.* Ф. Әмирхан. **Карт көндә** — *к.* картаймыш көндә. *Бирмәде бит карт көнемдә ходай малны.* М. Гафури.

◇ **Карт алаша** — һәртөрле әрсез эшкә күнеккән, күндәм һәм юаш карт ир кеше. *Карт алаша, — тарт, алаша.* (Карт кешегә яңадан-яңа эшләр йөкләү турында әйтелә.) Мәкаль. **Карт бүре** *сөйл.* — 1) күпне күргән тәжрибәле кеше. *Яганов эшкә каян тотынырга, ничек тәмамларга икәнен белә. Карт бүре. Егерме биш елдан артык эш тәжрибәсе.* Ш. Бикчурин; 2) шомарган, һәртөрле хәйләле, явыз эшләргә остарган карт кеше. [*Мине*] *Кәримовларның Шәрифҗан исемле бер карт бүресе алдады.* М. Фәйзи. **Карт карга** — күп сөйләүчән усал карчык-корчыклар турында. [*Вәли, җиргә төкерә:*] *Тфү! Карт карга, синең белән үбешергә дураклар дисеңме безне? Кызларыңны дим, кызларыңны үптер.* М. Фәйзи. **Карт төлке** — күпне күргән хәйләкәр кеше. *Камали абзый карт төлке бит. Боларның тәүбәсенә генә ышанмый, ошбу рәвештә протокол ясатты.* Ш. Мөхәммәдев. **Карт чыпчык** — төрле хәлләр кичергән, олы яшьтәге тәжрибәле кеше. *Карт чыпчыкны кибәк белән алдый алмассың.* Мәкаль. *Комиссар, әлбәттә, үзе дә күптәнге „карт чыпчык" иде, шуңа күрә үз алдында кемнәр утырганын бик тиз танып алды.* М. Әмир.

КА'РТА *и.* 1. Җир яки күк йөзенең төзелешен шартлы билгеләр ярдәмендә сурәтләгән сызым. *Географик карта. Күк картасы. Татарстан картасы.* □ *Наркомпрос кешесе карта янына килде һәм кызыл түгәрәк белән әйләндереп алынган күп авылларның берсенә төртеп күрсәтте.* Г. Гобәй. || Теге яки бу үзенчәлекле билгеләрнең яки хуҗалык тармакларының һ. б. урнашуын күрсәтә торган шундый ук сызым. *Казылма байлыклар картасы. Лингвистик карта. Этнографик карта. Туфрак карталары.*

2. Очколар санынча шартлы билгеләр, уен фигуралары һәм мастьлары төшерелгән кәгазь, картон кисәкләре, кәрт. *Уен картасы.* □ *Закир өстәлдә ята торган карта колодасын алып, хәзрәт каршысына килде.* Ф. Әмирхан. || Шундый карталар белән уйнала торган уеннар, кәрт уеннары. *Карта уйнау.*

3. Аерым белешмәләр теркәлә торган махсус графаланган кәгазь, бланк. *Курорт картасы тутырып, анализлар белән мәшәкатьләнеп ике-өч көн үтте.* Г. Мөхәммәтшин.

Карта ачу — 1) уендагы карталарның шартлы билгеләр төшерелгән ягын ачып салу; 2) *к.* карта салу; 3) яшерен серләрне, эчке ниятне белдерү, сөйләп бирү. *Барысыннан да бигрәк Галимулла әтәчләнде: — Хәзер карталарны ачып сөйләргә вакыт.* К. Нәжми. — *Эшләр зурга китсә, барлык карталарны ачып салачакмын.* Г. Әпсәләмов. **Карта салу** — 1) уен карталары буенча күрәзәләгәндә аларны билгеле тәртип буенча тезеп чыгу; 2) уен карталары буенча күрәзәләү. *Маһикамал чегән хатыннарыннан карта салдырды.* Л. Гыйльми. **Карта сугу** — кәртле уйнау. **Картага алу (алыну)** — *к.* картага төшерү (төшерелү). **Картага төшерү (төшерелү)** — 1) билгеле бер җир яки күк участогының картасын сызу. *(Миләүшә] җир катламнарын картага төшерүче партиягә коллектор итеп алдылар.* М. Әмир; 2) кирәкле объектны картада сурәтләп кую, картага кертү. *Григорян Газинурның әйткәннәрен картасына төшерде дә дошманны өзлексез күзәтергә кушып китеп барды.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Картага кую (куелу)** — зур хәвеф астына кую (астында тору), язмышың очраклылыкка бәйле булып калу турында. *Илдә революциянең яшәве картага куелган заманда кулларыбызны баглап утырасыбыз килми.* Ш. Усманов. **Картага кую** — берәр нәрсәне югалту куркынычына карамыйча тәвәккәлләү. *Бөтен халыклар --- китте сугышка, җаннарын куеп эшче ирке өчен картага.* Г. Камал. **Карталарны бутау** — күп төрле факторларны исәпкә алып корылган катлаулы бер планны көтелмәгән бер эш яки чыгыш белән җимереп ташлау, бозу. *Хәмитнең, барлык карталарны бутарга тырышып, бөтен гаепне үз өстенә алуы нигә хаҗәт булган?* А. Расих.

КАРТА (қарта) *и.* 1. Күшәүче хайваннар ашказанының алгы аерым өлеше. *Гажәп таныш ис аның [Габдулланың] борынын кытыклады: пешкән карта исе.* Ә. Фәйзи.

2. *диал.* Тукыманы җыерып тегү юлы белән ясалган бизәк, бөрмә бизәк.

КАРТАЕЛУ *з-сыз ф.* Күпне кичереп яки гомер узып, олы яшькә җитү. *Яшьлек үтте, инде картаелды, Яшим хәзер читтә, ышыкта.* М. Җәлил.

КАРТАЙМЫШ: картаймыш көндә — картайгач; картлык чорында. *Төпчегең — картаймыш көнеңдә ярдәмчең.* Мәкаль.

КАРТАЙТУ *ф.* 1. *Йөкл. к.* картаю. || Организмны таушалдыру; йончыту. *Егетне кыз, ирне тоз картайта.* Мәкаль. *Эш картайтмый, кайгы картайта.* Мәкаль. — *Газизнең үлүе бер картайтты, хәзер монысы икенче картайта.* Г. Бәширов.

2. Картка санау. *Газинур „апа" дигәч, Мәйсәрә тагын да кызара төште. — Ул хәтле картайтмасаң да ярар инде, — диде ул, елмаеп.* Г. Әпсәләмов.

КАРТАЛАНУ *ф.* Карта сыман катлы-катлы булып тору, кырык картага охшап катлану (тән, тире турында).

КА'РТАЛЫ *и.* Карталар белән уйнала торган уен, кәртле. [*Алафузовның*] *йөзе көләч, күзләре шундый ягымлы, аның, эшчеләр әйткәнчә, рәхимсез булуына, эчеп, карталы уйнап йөрүенә ышанасы килми.* Г. Гобәй.

КАРТАМАН *и.* Юлбасарлар башлыгы. *Картаман картайса ялганчы булыр.* Мәкаль.

КА'РТАЧЫ *и.* Карта уйнаучы, кәрт уены белән мавыгучы; картежник. *Исерек картачылар компаниясе бер минут гажәпсенеп карадылар да, ава-түнә, Булатовны сырып алдылар.* Г. Ибраһимов.

КАРТАЮ *ф.* 1. Олы яшькә җитү. *Менә хәзер икебез дә картайдык, чәчләребез агарды.* Ш. Камал. *Гомәр абзый, инде сиң картайган, болай сакалыңны кырып йөрү бер дә килешми.* Г. Камал. || Картлык билгеләре күренү, олысыманлану, яшьлек сыйфатларын югалту. *Яхшыга төшкән [килен] ярпайган, яманга төшкән — картайган.* Мәкаль. *Маликның атасы Биктәһир бик картайды.* И. Гази.

2. *күч.* Искерү; муртаю, какшау. *Дүвәл заманнарда көне буе ачык, аның аркылы өзлексез йөреләп торыла торган бу картайган капка хәзер эчке яктан бикләнеп куелган иде.* Ф. Әмирхан.

3. Агачлану, сутсызлану, кату (үлән сабаклары, сусыл җимешләр турында). *Җир өемнәре --- картаеп катудан көпшәләнеп беткән кәҗә сакаллары белән капланган.* М. Хәсәнов. *Картайган кыярлар алар, орлык кыярлары.* М. Әмир. || Башаклары кибеп кату, бөртекләре җиргә коела башлау (ашлыклар турында). *Дүрт-биш көн эчендә урып та, җыеп та өлгерергә исәп. Арышка картаерга ирек куймаска кирәк.* Х. Госман. || Артык сусызлану, үзлелеген югалту, кату

(камыр, измә турында). *Хатын-кызлар --- берсе икенчесен ашыктыра-ашыктыра кайнашырга тотынадар:— Токмачыңның камыры картая.* Ф. Хөсни.

4. *күч.* Үз вакыты, үз чоры узу; әһәмиятен югалту. *Бөек кешеләр бервакытта да картаймыйлар.* А. Шамов. || Сазау (кияүгә чыгу вакыты узу). *Кыз, азрак картайса да, Сайлый белде кияүне.* Ш. Камал.

Картайган көндә — *к.* картаймыш көндә. *Әгәр Хәйдәргә берәр хәл булса, [Мәүлихә тути] картайган көнендә япа-ялгыз калачак иде.* Г. Бәширов.

КАРТВЕЛ *и.* Грузиннарның җирле атамасы. || *с. мәгъ. Картвел телләре* [кавказ телләре семьялыгының бер группасы].

КАРТӘЖНИК *и. иск.* Кәрт уйнап кәсеп итүче кеше. *Ничектер, Урал ягыннан атаклы картежник килә.* Ф. Хөсни.

КАРТЕЛЬ *и.* Капиталистик монополияләрнең бер формасы — промышленностьның бер үк тармагында эш йөртүче капиталистлар союзы. *Яшерен картель электр лампочкаларыннан алып гигант турбогенераторларга кадәр барлык электр җиһазларына бәя билгели.* Соц. Тат.

КА'РТЕР *и.* Двигательләрнең аскы өлешен тузаннан, пычрактан саклау, май салу өчен һәм двигатель корпусына нигез булып хезмәт итә торган металл савыт. *Богатырев үлчәүле савыт белән алып килеп картерга май салды.* Ф. Хөсни.

КАРТЕЧЬ *и. иск.* Вак-вак түгәрәк һәм яссы кургаш кисәкләре тутырылган снаряд.

КАРТИ'НА *и.* **1.** Сәнгать әсәре итеп каралган буяулы рәсем. *Стенага майлы буяу белән эшләнгән кечерәк бер картина эленгән. Картинада: куе нарат урманы, баласын иярткән бер болан.* А. Шамов. *Сәлимнең күзләре тарихи зур фаҗигане чагылдырган картинага төште.* Г. Гобәй.

2. *сөйл. к.* кинофильм. *Төшке ашны ашаганда, Рәшитнең абыйсы:— Әнием, бүген кинода „Полк улы“ дигән картина күрсәтелә икән, — диде.* А. Әхмәт. *— Бергә картина карап утырудан нәрсә булган, ди! Бардык, карадык.* Ш. Камал.

3. *күч.* Күз алдындагы күренеш, манзара; панорама. *Айның күтәрелүе белән кыскара барган агач күләгәләре Хәятнең күңелендә хыялый картина тудырдылар.* Ф. Әмирхан. || Тормыш күренешләре, вакыйгалары һәм хәлләр. *Көндәлек тормыш картиналары.* □ *Сәрвәр хатны укып чыкканнан соң, карават башына сөялеп, уйга калды. Аның күз алдыннан бик күп картиналар тезелеп үтте.* Ф. Хөсни. || Гомуми бер хәл, ситуация. — *Мин уйлыйм, иптәшләр, безнең күз алдыбызда ачылган күңелсез картина безне һич тә куркытмаска тиеш.* Ш. Камал.

4. Драматик әсәр бүлекчәсе. *Өченче актның береңче картинасы Галимәнең трәгедиясен тирәнәйтә.* М. Җәлил.

КАРТИ'НКА *и.* **1.** *сөйл.* Китаптагы рәсем, иллюстрация. — *Нәрсә картинка карап утырасың? Төя тизрәк!— дип кычкырган тавышка Хәлим арбадан очып төште дә баскыч алдында өелеп торган китапларны җәлт-җәлт арбага сала башлады.* И. Гази.

2. *күч.* Бик матур йөз, гәүдә, сын. *Минем кара айгыр ничек уйнап тора иде. Картинка иде, үзең беләсең.* С. Рафиков.

◇ **Картинкадагы кебек** *сөйл.* — бик матур, көяз, купшы. *Өйнең уң ягында шундый үк калай башлы яңа капка — ачып кергәндә биге, туй кыңгыравы кебек, уйнап кала. Бөтен нәрсә үз урынында, бөтен нәрсә картинкадагы кебек.* Ф. Хөсни.

КАРТ-КОРЫ *җыйг. и.* Картлар һәм карчыклар, олыгайган кешеләр. *Айтуган һәм аның янындагы бер-ике карт-коры, үзләрен олылап телгә алганга күңелләре булып, сакалларын селки-селки башларын кагып алдылар.* Г. Бәширов. *Беркөн эштән туктагач, Карт-корылар йоклагач --- Миңлекәйне күрдем мин.* Ф. Бурнаш.

КАРТЛА'РЧА *рәв.* Картларга хас булганча; картларга охшатып. *Картларча кылану. Картларча әкрен атлау.* □ *Рәхим абзый картларча ашыкмыйча, ягымлы итеп сөйли башлады.* Г. Әпсәләмов.

КАРТЛАЧ *и.* Картайган, олы яшьтәге кешегә шаярып яки шелтәләп әйтелә. *Степанов --- калын олтанлы шактый таза ботинкасын [сузып]: — Мә, картлач, рәхәтләнеп ки, минем төсем булсын, — диде.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Картайган, олы яшьтәге. *Күптән инде синең азаныңны Тыңлый иде картлач бабайлар.* М. Крыймов.

КАРТЛЫК *и.* **1.** Карт булу хәле, сыйфаты. *Картлык белән фәкыйрьлек ике дошман, бу ике дошман белән юлга чыкмаң.* Мәкаль. *Белмим, хәле беткәнгәме, яки картлыктанмы, бу карт йокыга китте.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Гомернең ахыргы дәвере. *Картлык чоры.* □ *Яшьлегендә яшьнәмәгән картлыгында кала алса да, танылмас.* Мәкаль.

Картлык көне — гомернең ахыргы чоры, картаймыш көн. [*Мәрьям:*] — *И балалар, балалар, ник безне картлык көнебездә болай рәнҗетәсез.* Ф. Әмирхан. *Ай ялгыз ул картлык көнендә, Өйләнәлми калган, Шуның өчен Кайгы нуры күренә йөзендә.* Һ. Такташ.

КАРТОГРА'ММА *и.* Билгеле бер территория буенча билгеле бер күренешкә караган аерым статистик мәгълүматлар күрсәтелгән карта. *Алик --- кайсы басуга күпме һәм нинди ашлама кертү турында туфрак картограммалары төзетте.* Каз. утл.

КАРТО'ГРАФ *и.* Карта төшерү белгече. *Картограф өлгермәгән аны Карта битләренә язарга; Ләкин ул [шәһәр] бар.* С. Урайский.

КАРТОГРА'ФИК *с.* **1.** Картография күрсәткән яки картография өчен, картографиягә бәйләнешле. *Картографик экспедиция.*

2. Географик карталар эшләп чыгару белән шөгыльләнә торган. *Картографик фабрика.*

КАРТОГРА'ФИЯ *и.* Карта төшерү фәне; карта төшерү эше.

КАРТОН *и.* Калын каты кәгазь, катыргы. *Картоннан ясалган тартма.* | *с. мәгъ. Картон уенчык.*

КАРТОТЕ'КА *и.* Белешмә характерында яки санлы мәгълүматлар һ. б. язылган катыргы кәгазьләрнең системалаштырылган җыелмасы. *Китап күргәзмәләре, тематик плакатлар, картотекалар --- китапханәче кулы белән эшләнгән.* Соц. Тат.

КА'РТОЧКА *и.* **1.** Кечерәк кенә дүрт почмаклы кәгазь яки катыргы кисәге, картотека кәгазе. *Ишеккә кагылган карточкага --- „Тимофей Алексеевич Богданов“ дип язылган иде.* Ф. Әмирхан.

2. Дүрткел кәгазьгә төшерелгән фотографик рәсем, фотография (фотографик карточка). *Карточканы кулыма алып карарга керештем. Өч кеше: уртада карчык, бер ягында улы, икенче ягында кызы басып тора.* Ф. Кәрим.

3. Кешенең исем-фамилиясе һ. б. ш. язылган яки аның билгеле бер продукт, әйбер алырга хокукы белдерелгән талоннардан торган кәгазь кисәге, бланк. *Сугыштан соңгы авыр еллар иде бу. Икмәкне карточка белән нормалап кына бирәләр.* А. Расих.

Карточка системасы — беренче хаҗәт предметларын (азык-төлек, кием-салым һ. б.) карточкалар буенча халыкка тигез өләшеп сату системасы.

Карточкага төшерү (төшү) — фотографиягә алу. *Фотографик аппарат белән рәсем төшерү (рәсемгә*

төшү). □ *Фотокорреспондент бөгелә-сыгыла ялтйолт иттереп карточкага төшерә.* М. Хәсәнов.

КАРТУЗ *и.* Козыреклы баш киеме — фуражканың бер төре. *Крестьян батырып кигән картузы астыннан Илсеяргә карап-карап торды.* Г. Гобәй.

КАРТСЫНУ *ф.* Картрак дип санау, карт дип хисаплау. *Шәрәфи карт карчыгына: — Син генә юләр бит, мине картсынган буласың! — диде.* Ш. Камал.

КАРТЫ-ЯШЕ *җый. и.* Төрле яшьтәге кешеләр. *Колхозның карты-яше, хәл белергә дип, шул ук сәгатьтә аның [Гали абзыйның] йортына агыла башлады.* Г. Әпсәләмов.

КАРУ *и. сир.* **1.** Каршылык, тискәрелек; үч, үчегүчәнлек. *Каруга кару, карт алашага ябу.* Мәкаль.

2. *диал.* Авыр хәл, кыенлык. *Сөйгәнемне ятлар алды, Шуңа төштем мин каруга.* Җыр.

Кару кайтару — 1) әрепләшү, талашу. [*Бәдигыльҗамал:*] — *Анда синең эшең булмасын. Миңа кару кайтарма.* Г. Камал; 2) к. каруын алу. *Монысы былтыргы җәфаларның каруын кайтарырга булыр.* Р. Төхфәтуллин. **Кару саклау** — үч саклау. *Әйтә дә кайта ул безнең әни. Кару саклап йөрми.* Б. Камалов. **Каруын алу** — бер урында отылганлык, бер җәһәттән уңышсызлык бәрабәренә икенче урында, икенче очракта оту, уңышка ирешү. *Эшнең һәр ягы күңелсез булуының каруын сабактан ала идек.* М. Гафури.

КАРУЛАНУ *ф. к.* карулашу. *Әмма хәзрәт ничек кенә каруланмасын, сыерларны аның үзенә барып алырга туры килде.* С. Рафиков.

КАРУЛАУ *ф.* Киреләнү, карышу; баш тарту; баш бирмәү. *Давыт машинаның серләрен төшенеп алды. Комбайны карулый башласа да хәзер көйгә китерә.* Р. Төхфәтуллин.

КАРУЛАШУ *ф.* Карышу, тарткалашу; каршы килү, каршы тору, сүз тыңламау. *Карулашты дүхәди, Капчык бераз шиңгәч кенә Татулашты дүхәди.* Ә. Фәйзи. *Мин берәр төрле карулаша башласам, тыңламасам, хәзер күз алдыма Алмачуарны китереп куялар.* Г. Ибраһимов. || Каршы җавап кайтару, әрепләшү. *Олылар әйткәнгә карулашу.*

КАРУЛЫ *с.* **1.** Җавабы кайтарыла, хакы чыгарыла торган. *Икмәк-тоз карулы.* Мәкаль.

2. Үчле, кара әчле, ачу саклаучан. *Карулының тозагы корулы.* Мәкаль.

КАРУЛЫК *и.* Каршылык, кискен ризасызлык. *Кара әчле залимнар Сине, ярлы, тунады, Карулык кылсаң бераз, Бәйләп алып кыйнады.* Н. Арсланов.

КАРУН *и.* Бик саран һәм вакчыл кеше. *Үзем телим, куям ләкин үземә киртә, Байлык җыеп ач торган бер карун төсле.* Ш. Мөдәррис. — *Монысы тагын бер тамчы соляркасын кызганган була, карун!* Н. Фәттах. | *с. мәгъ. Авылның карун байлары пыран-заран китерелгәч, басулар киңәеп, елгалар тирәнәеп, урманнар куерып китте.* Г. Галиев.

КАРУНЛАНУ *ф.* Артык саранлану, вакчыллану. — *Карунланма, Нәбиуллин, монда ярминкә дә, базар да түгел. Сатулашма!* С. Рафиков.

КАРУНЛЫК *и.* Үтә саранлык. *Шәвәлинең хатыны— карунлыгы белән авылда дан тоткан Мәгыйшә — каенанасын үзләренә алдыруга теше-тырнагы белән каршы торды.* Г. Ахунов.

КАРУРМАН *и.* **1.** Зур, карт агачлардан торган куе, зур урман. *Су анасы, Шүрәле кебек мифлар Идел буенда — зур елгалар, карурманнар илендә туган булырга тиешләр.* Х. Госман. *Вятка аръягында, ераклта, зәңгәрсу рәшә эчендә иксез-чиксез карурман сузылып киткән.* Э. Касыймов.

2. *күч.* Тотынырга куркыныч эш; артык катлаулы нәрсә. *Мотор дигәнең минем ише мич капкачыннан ерак китмәгән кешеләр өчен генә карурман икән ул.* Ф. Хөсни.

КАРУСЕ'ЛЬ *и.* **1.** Үзәк багана тирәсендә әйләнеп торган баскычлардан яки ат, дөя һ. б. сыны рәвешендә ясалган утыргычлардан гыйбарәт аттракцион корылма. *Өсте кызыл белән япкан, читенә төрле төстәге матур шарлар таккан карусель гармонь, барабан тавышлары астында җилфердәп әйләнә.* Ф. Кәрим. *Көймәле карусельгә утырып әйләнүе яки таган атынуы нинди рәхәт!* Ж. Тәрҗеманов.

2. *тех.* Бер үзәк тирәсендә әйләнүче мәйданчыклардан торган корылмалар; авыл хуҗалыгында — механик саву җайланмасы. *Фермага карусель урнаштыру. Карусель ясау.* | *с. мәгъ. Карусель станоклар.*

КАРУСЕЛЬЧЕ *и.* Карусель (1 мәгъ.) әйләндерүче, карусельдә эшләүче кеше. *Иртәгесен, ул [Фәйзүк] --- тагын кичәге урынга — карусель янына йөгерде. Карусельчеләр аны әллә кайчангы танышлары күк итеп, көлеп каршыладылар.* Ф. Хөсни.

КАРУСЫЗ *с.* Күндәм, каршылыксыз һәм һәрвакыт хәзер. *Ул [Тимери] эшкә бик батыр, карусыз кеше иде.* Г. Бәширов. *Түтәй карусыз. Ул бөтен эшне әнәй кушканча эшли.* Ш. Маннур. | *рәв. мәгъ. — Әйткән сүзем, биргән әмерләрем Үтәлергә тиеш карусыз.* Т. Гыйззәт. || Тел-тешсез, көчсез, ярдәмсез. *Күрсәткән бу хатын безгә үги ананың ни икәнен. Биргәк тә миңа, карусыз сабиягә.* Э. Касыймов.

КАРУСЫЗЛЫК *и.* Күндәмлек, тыңлаучанлык. *Каюм — өлгерлеге, карусызлыгы белән һәркем тарафыннан ихтирам ителә торган стажлы эшче.* Г. Ахунов.

КАРХ *авазияр.* Йөткерү тавышын белдерә. *Карх итү. Карх-карх итү.*

КА'РЦЕР *и.* Тоткыннарны аеруча авыр шартларда ялгызын тоту өчен махсус камера, хәбесханә. *Зиндан башлыгының урынбасары, камераларга йөреп, тоткыннарны карап чыкканда, Гриша аягүрә каршы алмаган. Егетне өч көнгә икмәк-суга, караңгы, юеш карцерга ябалар.* Г. Ибраһимов.

КАРЧЫГА *и.* Урта зурлыктагы, кәкре томшыклы һәм озын тырнаклы ерткыч кош. *Бер көнне чыпчык үз өенә атылган уктай кайтып керде, аның артыннан күктә, биектә карчыга күренде.* А. Алиш. || *күч.* Бик кыю, үткен, житез кеше турында. — *Егет кенә түгел, карчыга ул безнең кияү.* М. Фәйзи.

◇ **Карчыга борын** — очы аскарак бөгелеп торган борын. [*Арслан*] *Кәримнең кәкрәеп килгән карчыга борынын, юешләнгән маңгаена ябышкан чәчләрен, төсе качкан һәм мәсхәрәле кыегайган усал йөзен күрде.* Г. Ахунов. **Карчыга булып ташлану** — зур җитезлек белән һөҗүм итү. *Кайсыдыр районның мебель комбинатыннан килгән вәкил директор өстенә карчыга булып кына ташланмый иде.* М. Хәсәнов. **Карчыгадан калган тавык шикелле** — бик өтек, сәләмә. *Карчыгадан калган тавык шикелле йолкынып, яраланып беткән алмагачларны кызганып, Гаяз бакча эчендә бик озак йөрде.* И. Гази. **Карчыга кебек** — җитез, үткен, чая, батыр. *Вәдүт дускай! Яшь карчыга кебек идең бит син сугыш кырында.* Ш. Маннур.

КАРЧЫК *и.* **1.** Олыгайган, картайган хатын-кыз. *Капкадан көянтә-чиләк күтәреп бер карчык килеп чыкты. Хөббениса әби бугай.* Р. Төхфәтуллин. || Олы яшьтәге хатын-кызның исеменә яки кушаматына өстәп әйтелә торган сүз. *Габдулла Саматовның фронттан сау кайтуына әнкәсе Нәгыймә карчык һәм туганнары --- бик шатландылар.* Ш. Камал. || Олы яшьтәге ир кешенең хатыны турында. *Гафият карчыгы, бисмилла әйтеп, юкә яфраклары арасыннан күренеп торган кып-кызыл, камыр күк булып пешкән өч-дүрт җиләкне су чиләге эченә дөп итеп төшерде.* М. Гали.

2. Олы яшьтәге ирләрнең үз хатыннарына эндәшү һәм аларны атау сүзе. *Гайҗан бабай, кеткел-кеткел көлеп ... — Чынлапмы бу, карчык, уйнапмы бу?—ди.* Ш. Маннур. *Син карчыгыңның күңелен ничек табып өлгерә аласыңдыр, юкса, минем карчык миңа бик еш үпкәли --- ни театрга, ни кунакка алып бармыйсың, ди.* А. Расих.

Карчыклар чуагы — *к.* әбиләр чуагы. *Бер мең тугыз йөз кырык дүртенче елның көзе явым-төшемле булдымы, яки карчыклар чуагы дип йөртелә торган кояшлы көз булдымы, ул хәтлесен кистереп әйтүе кыен.* М. Шәйми.

КАРЧЫК-КОРЧЫК *җыйг. и.* Карчыклар, олыгайган хатын-кызлар. *Усал идем, Карчык-корчыкларга Бик күп бәла-каза китердем.* Һ. Такташ. *Иртә белән янгын сарае алдында карт-корылар һәм карчык-корчыклар гына җыелды.* М. Шабай.

КАРЧЫКЛА'РЧА *рәв.* Карчыкларга хас булганча; карчыкларга охшатып. *Патый әби, өстен чишенеп, карчыкларча вак һәм йомшак кына басып, түргә узды.* А. Шамов. *Хәтимә абыстай карчыкларча ике кулын да итәгенә куйган.* Ш. Мөдәррис.

КАРШЫ I *с.* **1.** Күз алдындагы, билгеле бер нәрсәнең алгы ягына (ишегенә, фасадына һ. б.) капма-каршы яктагы. *Каршы урам. Каршы йорт.* □ *Фәхри бабай каршы өйгә чыккан иде.* М. Гафури. — *Туңдыңмы? — дип сорады каршы койкада утырган Гарәфи абзый.* Г. Әпсәләмов.

2. Сөйләүче (яки сөйләүченең игътибарында торган объект) белән көрәшүче, дошман. *Каршы як. Каршы гаскәр.* || Кире, тискәре, холыксыз. *Каршы кеше үенны бозар.* Мәкаль. || *диал.* Ярырга, эшкәртергә кыен булган. *Карама агачы — каршы агач.* Мәкаль.

3. Нәрсәне дә булса инкяр итә, шуны теләмәүне белдерә торган. *Каршы тавыш (бирү).* || *рәв. мәгъ.* Кире җавап бирәрәк, җаваплашып. *Фәтхия каршы әйтмәде, аның үз башы хәсрәт белән тулы иде.* Г. Ибраһимов.

4. *Хәб. функ.* Билгеле бер күренешкә, теләккә, хәкемгә каршылыкны белдерә. — *Очрашырга, сөйләшергә мин каршы түгел.* Ә. Еники. || Фикер алышканда яки җыелышта һ. б. берәр фикерне, тәкъдимне хупламауны белдерә; *киресе*: яклы. — *Димәк, [тәкъдимгә] каршы кеше юк? — диде Һидият. — Ул чагында тавышка куеп та тормыйм, Мостафа, син үзең дә каршы түгел бит?* Ш. Камал.

5. *и. мәгъ. юн., чыг., у-в. килешләрендә.* Күз алдындагы урын, алдагы як, алдагы юнәлеш. *Тирә-як тигез ачык ялан. Каршыда, без барырга тиеш якта, каен катыш имән урманы.* Ф. Кәрим. *Без авылга карап, бер җир буе да бармадык, каршыдан абзый килеп чыкты.* М. Гафури. *Сайрама агач башында, Сайра, былбыл, каршымда.* Җыр.

6. *бәйл. мәгъ.* **Каршында (каршында, каршысында).** Кемгә, нәрсәгә булса да билгеле бер (чагыштырулы, конфликтлы яисә әхлак-хокук даирәсенә караган) мөнәсәбәттә булуны белдерә. *Бахыр каршысында батыр, батыр каршысында үзе бахыр.* Мәкаль. *Күңелем пакь, сүзем хак, ил каршында йөзем ак.* Мәкаль. — *Сөләйман каршында мин үземне гаепле дип саныйм.* Ш. Камал. || Кемнең дә булса алдында, кемдер карап, күреп торганда. *Тимери уйга калды. Аланбашлар каршында колхозның болай оятка калуы аны аеруча гарьләндерде.* Г. Бәширов. *Патшаның түбәсе түшәмгә тия, сөенә, ят патшалар каршында мактана бу.* Әкият.

Каршы алу — 1) килүченең каршысына чыгу яки аңа игътибар юнәлтү, сәламен алу, аны сәламләү. *Ферма мөдире Миргали абзый Гатаны көлеп каршы алды, исәнлеген сорашкач, ферманы күрсәтә башлады.* А. Алиш. *Вахит абзый улы Галимуллага карап: — Днә, килеп тә җиттеләр, улым, бар каршы алырга чык әле, диде.* М. Гали; 2) берәр яңа вакыйгага, хәбәргә һ. б. билгеле бер мөнәсәбәт күрсәтү. *Яңа хәбәрне шик белән каршы алу.* **Каршы бару** — нинди дә булса эш яки фикер белән килешмәү; шуны инкяр итү; дәвамлы рәвештә актив карышу. *Табигать тә бикәнең теләгенә каршы бармады.* Г. Ибраһимов. **Каршы килү (чыгу)** — хупламау, риза булмау. — *Мин сиңа бюллетень язам, Газинур. Син берничә көн өйдә генә утыр, — диде Катя. Газинур каршы килде: — Кирәкми, кирәкми.* Г. Әпсәләмов. *Башка кандидатураларга каршы килүче булмаса да, Талипның кандидатурасына берничә кеше каршы чыкты.* Ш. Камал. **Каршы кую** — 1) нинди дә булса сыйфатларны ачыклау өчен ике нәрсәне чагыштыру. *Әдип [Г. Ибраһимов], Җәләл һәм Зөләйха сурәтләрен бер-берсенә каршы куеп, һәр икәвесенең ике угыл язмышына багланышларын күрсәтмәкче була.* Г. Нигъмәти; 2) дошманлаштыру, каршылаштыру. *Сәлим --- юлга чыккач, иптәшләрен үзенә каршы куюдан да курка иде.* Г. Әпсәләмов. **Каршы тору** — 1) каршылык күрсәтү, бирешмичә көрәшү. *Бергә каршы тордык дошманнарга, Бергә түктек кайнар каннарны.* Ә. Ерикәй. *Аңа [Кызыл байракка] нинди көч Каршы тора ала?* М. Гафури; 2) карышу; каршы төшү. *Җыелышны кич белән ясауга Сәләхи нык каршы торды.* Ш. Камал. **Каршы төшү** — ризасызлык белдереп яки кискен рәвештә каршы килү. *Мөхәммәтша кызының тормышка чыгуына каршы төшә.* М. Җәлил.

КАРШЫ II *бәйл.* **1.** Нәрсәгә дә булса карап урнашу мөнәсәбәтен белдерә. *Кояшка каршы [ачылган] тәрәзәләр. Мәйданга каршы йорт.* □ *Мин, скамья алып, Разияга каршы утырдым.* Ф. Әмирхан. || Билгеле бер нәрсәнең хәрәкәт юнәлешенә кире юнәлешне белдерә. — *Бурлаклар алар, улым, агымга каршы зур көймә өстерәп киләләр, — диде Габденнасыйр.* М. Гали. *Сабир абзый урыныннан торып, аңа каршы атлады: әйдүк, әйдүк, Сәйфулла!* Ә. Еники.

2. Билгеле бер вакыт җитә башлау мөнәсәбәтен белдерә. *Бер үзем дүрт ат белән кичкә каршы көлтәгә барырга булдым.* Г. Ибраһимов. *Таңны да көтеп тормадым, төнгә каршы юлга чыктым.* Х. Садри.

3. Берәрсенең яки берәр оешманың һ. б. омтылышын, хәрәкәтен яки нинди дә булса бер күренешне бетерергә, туктатырга теләү мөнәсәбәтен белдереп килә. *Сугышка каршы хәрәкәт.* □ *Хөкүмәткә каршы кешеләрне дә шунда [Себергә] сөреп җәза биргәннәр.* М. Гафури. *Хәлил белән Анатолий да --- көрәкләр күтәреп, чикерткә явына каршы чыгып киттеләр.* И. Гази.

4. Җавап булу, җавап кайтару мөнәсәбәтен белдерә. — *Юк, — ди Зәйнагыйттин аңа каршы, — миңа юаш ат кирәк.* М. Гали. *Хатка каршы иркәм язар хат, Хат алуы күңелгә рәхәт.* Ә. Ерикәй. *Сөләймановның: Я, кемгә сүз бирәбез соң? диюенә каршы, өченче рәттән колхоз умартачысы Нуретдин абзый урыныннан күтәрелде.* Ә. Еники.

5. Берәр нәрсәгә сәбәп булуны белдерә. *Бәхеткә каршы. Үкенечкә каршы. Кызганычка каршы.* □ *Минем гаять ачуыма каршы, тагы музыка башланды.* Ф. Әмирхан.

КАРШЫГА *рәв.* Каршы юнәлештә. *Идел өсте каршыга искән йомшак җил белән кытыршылана башлады.* К. Нәҗми.

КАРШЫДАШ *с.* Кара-каршы якларда симметрик рәвештә торган. *Каршыдаш ботаклар. Каршыдаш почмаклар.*

КАРШЫЛАНУ *ф.* Каршы, тискәре булып китү, киреләнү, карышу, сүз тыңламау. *Алай бик каршылан-*

саң, Алмачуарыңны тотарбыз да урманга җигәрбез, — дип куркыталар миңе. Г. Ибраһимов. || Каршы юнәлеш алу. *Кичкә калып җиләк җыйган киң урманда — Кайтканында кичке җилләр каршыланса --- Син шомланма, Гөлкәй!* М. Җәлил.

КАРШЫЛАУ *ф.* Каршы алу. *Бер төркем яшьләр, кунакларны каршылау өчен, басуга ук чыкканнар иде.* М. Гали. || *күч.* Яңарак килгән кешегә яки яңа күренешкә, вакыйгага, хәбәргә һ. б. билгеле бер актив мөнәсәбәттә тору. *Кыш буе сагынылган ул кояшны тереклек дөньясы елмаеп каршылый.* А. Алиш. || Билгеле бер вакыт берәмлеген, дәверне башлау, вакыйганың, күренешнең башланганын күрү. *Тирән окопта каршылыйм Икенче язны.* Ф. Кәрим. *Әлми Муса, тагын ниләр күрер һәм бу язны кайда каршылар?* Г. Хуҗи.

КАРШЫЛАШУ *ф. сир.* Каршы тору, карышу, каршылык күрсәтү. *Кулак хәзер яңа методлар белән каршылаша.* М. Җәлил.

КАРШЫЛЫК *и.* 1. Каршы булу, тискәрелек, кирелек. *Наданлыгы, каршылыгы сәбәбеннән Сусаган көе китте ишәк, ахмак.* М. Гафури. || Каршы тору, ризасызлык. *Бакуда нефть промыселларында --- патшага каршылыклар көннән-көн үсә.* Х. Садри.

2. *филос.* Табигать һәм җәмгыять күренешләренә хас булган үзара кире мөнәсәбәт, килешмәүчәнлек, кискен аерма. *Сыйнфый каршылык. Әчке каршылыклар.* □ *Габдулла мулла белән Г. Камал арасындагы фикер каршылыгы көннән-көн тирәнәя.* М. Гали. || Конфликт. *Каршылыксыз һәм көрәшсез драма әсәре була алмый.* М. Җәлил.

3. Комачау, тоткарлык. *Каршылыкка очрау.* □ *Кешегә үз юлында очрый торган авырлыклар, каршылыклар белән көрәшергә туры килә.* Г. Иделле.

Каршылык күрсәтү — көч белән каршы тору, каршы сугышу. *Без, солдат буларак, актык чарабызгача каршылык күрсәттек.* Ш. Маннур. **Каршылыгы сыну, каршылыгын сындыру** — мораль һ. б. басым ясап яки көч кулланып, кемне булса да җиңү, бастыру турында. *Ләкин иптәшләре каты-каты әйтә башлагач, Вәлиевнең каршылыгы озакка бармады, сынды.* С. Рафиков.

КАРШЫЛЫКЛЫ *с.* 1. Каршылыгы булган, каршылыклар килеп чыккан. *Каршылыклы хәрәкәт.*

2. Төрле фикерләр кузгата торган, катлаулы. *Андреевның беренче секретарь булып килүе Мостафинда әллә нинди сәер генә каршылыклы хис кузгатты.* Ә. Еники.

КАРШЫЛЫКСЫЗ *рәв.* Карышмыйча, киреләнмичә. *Каршылыксыз буйсыну. Каршылыксыз йомыш башкару.*

КАРШЫНДАГЫ *бәйл.* Нинди дә булса оешмага һ. б. буйсынган (шуның идарәсендә) булу мәгънәсен белдергән кушма аергыч ясап килә. *Губком каршындагы татбашбюро җитәкчесе — Сәмигулла.* Ш. Камал. *Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясе 1938 елның көзендә үзенең эшен төгәлләде.* М. Җәлил.

КАРЫГУ *ф. диал.* Җенси теләккә килеп, тыныч-сызлану (терлекләр турында).

КАРЫЗ *и. иск.* Бурычка бирелгән нәрсә, бурыч. *Карыз, карызны бирү фарыз.* Мәкаль. *Хажибаевка карызга биш йөз сум акча биреп торган идем.* Г. Газиз.

КАРЫЙ *и. иск.* Бик олыгайган, бик карт кеше. *Карый килсә сүз бетәр, Егет килсә эш бетәр.* Мәкаль. *Карый белән сабый бер хөкемдә.* Мәкаль. | *с. мәгъ.* — *Күңелегез булгандыр инде карый кешене шулай бимазалап йөрткәч!* Ф. Хөсни.

КАРЫЙЛЫК *и. иск.* Картлык, картайганлык. *Карыйлык килде миңа, тәкатем юк.* М. Колый.

КАРЫК *аваз [яр.* Каргылдау, карылдау авазын белдерә. *Ишек алдына чыккач та „каррык, каррык!" дигән ямьсез карга тавышы ишетелде.* Х. Кәрим.

КАРЫЛДАУ *ф.* 1. Бик тупас итеп каркылдау. *Өй түбәсендә кар-кар итеп карга карылдый иде.* Ш. Камал.

2. Тавыклар һәм тавыкка охшашлы кошлар өчен характерлы булган тамак тавышы чыгару. *Әтәч, бик аптырагандай, карылдап куйды.* М. Гали.

КАРЫЛУ *ф. диал.* Карлыгу, карлыга төшү. *Тагын да матур җырлар идем, Тамакларым карылган.* Җыр.

КАРЫМТА *и. тар.* Барымта белән талап алынган малны кайтарып алу өчен оештырылган һөҗүм, поход; кару кайтару, үч алу. *Таланган кабилә бер көнне үзе җавап һөҗүм ясый, моны „Барымтага карымта" дигәннәр.* Н. Исәнбәт.

КАРЫН *и.* 1. Күшәүче хайваннарның күшәлмәгән азык тула торган капчыксыман эчке органы. *Йотылган азык башта зур күләмле карынга әлгә.* Зоология.

2. Аш казаны. *Аю май кисәген йота. Май эрегәч, балык сөяге тураеп, аюның карынын ерта башлый.* Г. Әпсәләмов. *Бай тук була, ә ярлы ач — буш була карыны.* Н. Арсланов. || Корсак, эч. *Кабан кабанның карынын ярмас.* Мәкаль.

3. Аналык, бала урыны. *Карындагы бала — алынмаган кала.* Мәкаль. *Мондый җиргә рәзе тайлы бия җигеп киләләр. Сезнең бу дүрт аяклы төенчегегездән карын юеше дә кибеп җитмәгән.* Ф. Хөсни.

4. Карындыктан торган капчык, янчык. *Кайда булган безнең өч карын май?* Х. Кәрим. *Бер чеметем тоз, кечкенә кисәк икмәк катысы. Болар һәммәсе карынга төруле.* Г. Ибраһимов.

5. махс. Тиренең карын өлеше. *Бай хатыннары тун кия, атлас тун, гадәти төлке карыны әчле яки карсак карыны әчле.* К. Насыйри.

Карын ачу — ашыйсы килү, аш казаны тартылу. *Карыныбыз бик ачса да, иске гадәт буенча, урманны чыкканчы ашау юк иде.* А. Гыйләҗев.

КАРЫНДАШ *с.* Бер анадан туган; карендәш. *Арсланбай эшне җиңел өзде: — Безгә карындаш булган ике ыругның өлкәннәре биргән киңәшне бозарга амалыбыз юк.* Г. Ибраһимов.

КАРЫНДЫ *и. диал.* Яры, элпә. *Граф киемендәге кеше --- кесәсеннән әллә нәрсәләр чыгарды да үлем карындысы белән каплангандай күзе белән сөзде.* Т. Госман.

КАРЫНДЫК *и.* 1. Күшәүче хайваннар карынының стеналарын тәшкил иткән юка, нык яры (электә көнкүрештә киң кулланылган). *Ибәт абзагай --- хатыннар күренмәсен дип, тәрәзәсенә карындык корса да, Хәдичә абыстайны кыр хезмәтенә җибәрә иде.* З. Һади. | *с. мәгъ. Гөлнур, Сирай белән янәшә, тәрәзә төбенә утырып, карындык бөктәрне актара башлады.* К. Нәҗми *Карындык өлгеләр, бер әчкә, бер тышка таба кабарып, лап-лап иткән тавыш чыгаралар.* Х. Садри.

2. Бала сүрүе. *Бәхетле буласы бала карындыгын башына киеп туа, имеш.* Мәкаль.

Карындык боз — үтә күренмәле һәм тип-тигез көзге боз. *Көзге карындык боз.*

КАРЫН-КАРЫН *с.* Күп карындыкларга тутырып куелган. *Базар тулы ризык: капчык-капчык он, тушлап-тушлап сарык ите, карын-карын туңмай.* Ә. Исхак. *Сандыкларда өелеп ята торган карын-карын сары май --- хәзер бары төштә генә күрергә калды.* И. Салахов.

КАРЫНКЫ *с. диал.* Карлыккан, тоныкланган (тавыш турында). *Рәхим бераз карынкы, шулай да матур тавыш белән сөйли башлады.* Ф. Әмирхан. *Бабай, карама әченнән: Сөйлә! — ди карынкы аваз белән.* Әкият.

КАРЫНЧЫК *и.* Йөрәкнең кан әйләнешен тәртипкә сала торган өлеше. [*Йөрәк*] *ике яртыга бүленә. Бу яртыларның һәркайсы бер-берсе белән аралаша торган ике бүлектән: колакчыктан һәм карынчыктан тора.* Анатомия.

КАРЫШ *и.* Озынлык үлчәве берәмлеге — киерелгән кулның баш бармак очы белән урта бармак очы арасы, уртача чирек аршинга тигез. *Мөсәббикә буе ике карыш, иңе бер карыш булган агач тартма китерде.* Г. Галиев. *Аларның* [*Рәүфләрнең*] *тәрәзәләре җирдән бер генә карыш биек иде.* Г. Иделле.

КАРЫШЛАВЫК *и.* Киң канатлы күбәләкләрнең бик нык дугаланып, карыш белән үлчәгән шикелле хәрәкәтләнә торган яфрак ашаучы корты; *русчасы:* пяденица. *Карышлавык карышлап йөреп ашар.* Мәкаль.

КАРЫШЛАУ *ф.* 1. Берәр араны яки озынлыкны карыш белән үлчәү. *Тукыманың иңен-буен карышлау.* □ *Тегүче карчык буен карап та чамалый, ә кыз буен җиде карышлар, имеш.* Мәкаль.

2. *күч.* Кыйнау-сугу турында. *Становойның чигә тамырларын карышлаганнармы, зөбә кабыргаларын санаганнармы—аларны мин күрә алмадым.* Х. Кәрим.

КАРЫШУ I *ф.* Әйтелгәнне үтәүдән, кушылганга буйсынудан баш тарту, тыңламау, буйсынмау, киреләнү. *Дни минем шулай мәктәпкә барам дип аунап елаганымны күргәч, башымнан сыйпап: — Олылар сүзенә алай карышырга ярамый, улым, — диде.* М. Гали. *Гүзәл --- биргән даруларны карышмыйча әчте.* М. Хәсәнов.

КАРЫШУ II *ф.* Табигый булмаган рәвештә боргалану, кәкрәю; кәкрәеп кату. *Карышып үскән караманы турайталмассың.* Мәкаль.

КАРЬЕР *и.* Ачык ысул белән таш, балчык, руда һ. б. чыгару урыны. *Таң ату белән карьерга таш ватучылар, таш юнучылар, башка эшчеләр килделәр.* Ш. Бикчурин. *Тыныч еллардагы торф учакларыннан хәзер бары тик ташландык карьерлар, ишелеп төшкән канаулар гына калган.* Г. Әпсәләмов.

КАРЬЕ'РА *и.* 1. Хезмәттә, администрация баскычында һ. б. ирешелгән урын, авторитет һәм дәрәҗә. *Карьераны бозу.* □ *Үсеп барган карьераның, коммуна начальниклары алдында казанган ышанычның бер көн эчендә кинәт җимерелүе генә борчыды аны.* Л. Гыйльми.

2. *сир.* Билгеле бер өлкәдә эшләү, хезмәт. *Хәрби карьера юлын сайлау.*

КАРЬЕРАЧЫ *и.* Үз карьерасы өчен генә тырышучы. *Теңкәбезгә тигән карьерачы — Дәрәҗәгә менгән туң агай.* Ә. Баянов.

КАРЬЕРИЗМ *и.* Үз карьераң өчен генә тырышу күренеше. *Хезмәт положениесе белән файдалану һәм карьеризм фактларының тамырына балта чабыйк.* Ә. Фәйзи.

КАРЬЕРИСТ *и. к.* карьерачы. *Карьеристлар, шөһрәт сөючеләр Килә-китә, китә, онытыла.* Г. Афзал.

КАРЬЯ *и. иск. кит.* Авыл. *Өчиле карьясе* [*исемеңнән дә мәгълүм*] *бик кечкенә вә ярлы бер карья булганга --- бабайның көн күрмеше гаять начар булган.* Г. Тукай. *Хәлфәбез тотты да мәдрәсәбезне, мәдрәсәбезне генә түгел, карьябезне ташлап каядыр китте.* Ә. Еники.

КАС *хәб. сүз.* Үч, каршы, аеруча дошман. *Шырпы кулга кас, кылыч кынга кас.* Мәкаль. || Үзара үчеккән, дошманлашкан хәлдә. *Ике яхшы кас булмас, ике яман дус булмас.* Мәкаль.

КАСД, КАСТ *и. иск. кит.* 1. Теләк, омтылыш, максат, ният. *Ахыр ул* [*Әбүгалисина*], *гыйлем һәм хикмәт һәм мәгърифәт арттырмак касды белән, бөтен дөньяны гизмәк ният итте.* К. Насыйри. *Аждаһа елан койрыгы белән хан кызын чолгап алган, йоту касды белән авызына таба суырмакта иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Явыз ният, үч. *Яхшының дусты күп, яманның касты күп.* Мәкаль.

Касд кылу (итү) — 1) һөҗүм итү, һөҗүмгә килү. *Сәнәкләр, мылтыклар, этләр — барчасы моңар* [*аюга*] *касд кылалар.* Г. Тукай; 2) нәфес сузу, үчегү, яман ниятте тору. — [*Хәйри*] *кеше бәхетенә касд кылганчы, аллаһы тәгаләдән үзенә сораса ни булыр иде?* Г. Ибраһимов. — *Шулай ук җен-пәри дигән нәрсәләр адәм балаларына зыян-зарар китерергә касд итеп кенә торалар, — диде мулла.* М. Гафури; 3) билгеле бер максат куеп омтылу. *Бөеклеккә касд итү.*

КАСДАН *рәв. иск.* Юри, хәйлә белән. *Юк, бәлки ул* [*туташ*] *онытып түгел, касдан калдырып киткәндер* [*рәсемен*]. Ф. Әмирхан.

КАСДЛЫК *и.* Касд (2 мәгъ) булу, үчлек. *Кешегә касдлык итү (кылу).*

КА'СКА *и.* Башны пулялардан, ярчыклардан, бәрү-сугулардан саклау өчен металлдан эшләнгән тирән баш киеме (гадәттә гаскәриләр һәм янгынчылар кия). *Кидем башка корыч каскамны, Гранатамны билгә асканмын.* Ф. Кәрим.

КАСКАД *и.* Елга агымы буйлап бер-бер артлы төшә торган шарлавыклар яки шулар урынына корылган электростанцияләр системасы. *Ангарада электр станцияләре каскады елга 70 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе бирә алачак.* СССР физ. геогр. || *күч.* Бер-бер артлы булган күренешләрнең алмашынып торуы, тыелгысыз көчле агымы. *Бер якта --- ялгызлык. Икенче якта музыканың мәһабәт каскадлары.* Ш. Хөсәенов. *Югары пилотаж фигураларын башкару өчен Анисимов чакырылды. Ул --- фигуралар каскадын уңышлы башкарып чыкты* С. Баттал.

КА'СКАЛЫ *с.* Каскасы булган; каска кигән. *Ә бәрәңге бакчасының Тирәсе — яңа читән; Каскалы сакчылар сыман, Һәр казык чүлмәк кигән.* С. Баттал.

КАСКЕ'ТКА *и.* Җиңел фуражканың бер төре. *Килүченең кулында винтовка, үзе мәче кебек посып атлый, зәңгәрсу-соры каскеткасына кара канат кыстырган.* Г. Әпсәләмов.

КАСМАК *и.* 1. Нәрсәнең дә булса савыт төбенә утырган, көеп ябышкан калдыгы. *Касмак кыру. Бутка касмагы.* □ *Минһаҗ шаярып: — Их, Гөлбану касмак яраткан икән! Туе нинди буранга туры килә, — ди.* Г. Ибраһимов. || Кабык булып ябышкан юка катлам. *Хлорид кислотасын металларны тутыктан һәм тимер касмагыннан чистарту өчен файдаланалар.* Химия.

2. *диал.* Өре, элпә. *Шулпа касмагы.*

КАСМАКЛАНУ *ф.* Касмак белән каплану; пычрану. *Бу җиңнәр хәлфәгә кулъяулыгы хезмәтен үти, ахры, касмакланып беткәннәр.* К. Нәҗми.

КА'ССА *и.* 1. Акчалар һәм кыйммәтле кәгазьләр саклана торган шкаф, тартма, шкатулка һ. б. *Кибетчеләр зар елыйлар:* [*Закир*] *кассадагы акчаны ала да чыга да китә, чыга да китә, диләр.* Г. Камал.

2. Акчалы операцияләр (алу-бирү, билет сату) алып барыла торган бүлекчә. *Колхоз кассасына безнең команда* [*бригада*] *быел дүрт мең сум керттте.* Г. Галиев. || Шундый бүлекчәнең эш бүлмәсе яки эш өстәле, эш тәрәзәсе. *Чират торам касса төбендә, Акча алып кайту күңелдә.* Г. Афзал. *Касса ябылган-*

чы, ничек кенә булса да барып җитәргә һәм билет алъктереп калырга кирәк. Г. Мөхәммәтшин.

3. Төрле кредит учреждениеләре. *Саклык кассасы.* □ *Һарун авылга мең ярым акча салды - - - кассага салыгыз, диде.* Н. Фәттах.

4. *махс.* Типографиядә шрифтлар алфавит тәртибендә тутырылып куелган күп оялы тартма, әржә. *Күк күлмәген кигән наборщиклар Кассаларга килеп бастылар.* М. Крыймов. *Хәреф кассалары тирәсендә чуалгалыйм, хәреф җыярга өйрәнеп маташкан булам.* Ф. Хөсни.

КАССАП *и. кит.* 1. Мал суючы эшче. *Сарыкның үлеме кассаптан.* Мәкаль. *Карап торып өйрәнеп булса, эт кассап булыр иде.* Мәкаль.

2. Мал сую белән шөгыльләнә торган предприятие (кярханә), бойня. [*Хәсәнша*] *мойкада йон юуны тикшерә, кассапта мал суюны караштыра.* Ш. Камал.

КАССАПЧЫ *и. к.* кассап (1 мәгъ.) *Кассапчыга май кайгы, Кара кәҗәгә җан кайгы.* Мәкаль. *Кассапчы бит ул* [*Габделбәр*]. *Мал суйдыра. Нәпман.* А. Расих.

КАССАПЧЫЛЫК *и.* Кассапчы эше, кассапчы һөнәре.

КАССА'ТОР *и.* Судның икенче инстанциясенә жалоба бирү, беренче баскычтагы судның карарын үзгәртүне таләп итүче, кассация (2 мәгъ.) бирүче шәхес.

КАССАЦИОН *с.* Кассациягә бәйләнешле.

КАССА'ЦИЯ *и.* 1. Түбән баскычтагы суд чыгарган карарның югары инстанциядә яңадан каралуы һәм шуның рәсми тәртибе.

2. *гади. с.* Суд карарыннан ризасызлык белдереп, югарыгы судка бирелгән гариза.

КАССЕ'ТА *и.* 1. Тәбәнәгрәк, ләкин чагыштырмача киң һәм озын итеп, төрле максатлар өчен ясалган металл тартма, „кечкенә касса". || Фотографиядә: пластинкалар өчен яктылык кермәслек итеп ясалган футляр. *Фоторәсем төшерүгә хәзерлек кассеталарны һәм аппаратны корудан башланып китә.* Фотосәюче.

2. Бомбардировщикларда: бер-бер артлы бомбалар төшерү өчен җайланма. *Самолетлар, вак бомба тутырылган кассеталар ташлап, мөмкин хәтле күбрәк үтерергә тырыштылар.* Ш. Маннур. || Бал агызгычта: баллы кәрәз куела торган челтәр стеналы читлек. *Иң гади конструкцияле бал агызгычларда кассеталар барабанга беркетеп куела.* Умартачылык.

КАССИР *и.* Кассада акча операцияләрен башкаручы. *Кассир Гыймай кичә бездә булды. Госбанктан кайтып барышлый.* М. Җәлил. *Баштарак колхозда кассир-хисапчы, соңгы елларда бухгалтерлык вазифасын алып баручы бу кешене һәркем белә иде.* С. Рафиков.

КАССИРЛЫК *и.* Кассир эше. *Сания кулындагы дәфтәрләрне өстәлгә куеп, урынына утырырга өлгермәде, мәктәптә секретарьлык һәм кассирлык хезмәтен алып баручы ханым аңа зур конверт китереп тоттырды.* М. Әмир.

КАССИ'РША *и.* Кассир булып эшләүче хатын-кыз. [*Бану:*] *Кассирша булып гомеремне черетмәс идем. Туйдым кассирша булудан. Көнозын акча санап утыр имеш.* Р. Ишморат.

КА'СТА *и.* 1. Һиндстанда үзләренең чыгышлары, кәсепләре, иҗтимагый хәлләре буенча аерымланып, башкалар белән якын аралашмый торган кешеләр группасы, социаль катлам. *Бер төр һөнәр кешеләре, һинду дине күрсәтүе буенча, аерым каста тәшкил иткән.* М. Мәхмүтов. *Һиндстан халкы дүрт кастага бүленгән. Югары кастага брахманнар, икенчесенә сугышчылар, өченчесенә крестьяннар һәм сатучылар, түбән кастага ялчылар кергән.* Урта гас. тарихы.

2. *күч.* Башкалар белән аралашмый торган иҗтимагый группа. *Дворяннар кастасы.*

КАСТА (каста) *и. диал.* 1. Авыру, чир. *Мөҗип кызышып авырып ята икән. Сәйфетдин аны юатып әйтә икән: — Зарар юк, каста үтә дә китә, үләргә генә булмасын.* Н. Исәнбәт.

2. *с. мәгъ.* Хаста, чирле. *Каста бул минем өчен, Улием синең өчен.* Мәкаль. | *и. мәгъ. Каста үлми, карак баемый.* Мәкаль.

КАСТАЛАНУ *ф. диал.* Авыру, чирләү. — *Абзыең үзе касталанып ята. Айшә базарга китте.* А. Расих.

КАСТОР: кастóр мае — эч катудан дәва итеп кулланыла торган дару.

КАСТРЮ'ЛЬ *и.* Цилиндрик формадагы металл савыт. *Ак кәпәч, ак казаки кигән, яныпешеп чыккан пешекче, кисмәктәй зур кастрюльләрнең әле берсен, әле икенчесен ачып карый.* Г. Гобәй.

КАСЫЙДӘ *и.* 1. *кит.* Шәрык поэзиясендә ода формасы — баштан ахырынача бер рифмага тезелгән озын шигырь. *Бу Габделмән* [*үз*] *заманасының билгеле кешесе булган дип уйларга кирәк. Аның турында Сәфәр мелла Салих углы да бер касыйдә (мактау шигыре, мәдхия) язган.* Х. Хисмәтуллин. *Кара такталар тоткан ачык йөзле кечкенә шәкертләр тезелеп - - - касыйдәләр укый башладылар.* Х. Кәрим.

2. *иск.* Кызлар исеменә мәдхия, ода язуы яшерелгән бөти (кызлар аны чәчүргечкә тагып йөрткәннәр). *Чәчкә касыйдә тагу.*

КАСЫК *и.* Гәүдәнең корсактан түбәнге өлеше белән бот төбе арасы. *Күкрәктәге авырту касыкка төште.* Н. Фәттах. *Сыерларның - - - йоннарына кадәр коелып беткән. Касыкларына карга ояларлык.* М. Хәсәнов.

КАСӘ *и.* 1. Кисек конус формасындагы пыяла яки фарфор савыт, тоткасыз чынаяк. *Муса әфәнде хезмәтчене чакырып, берәр касә кофе китерергә кушты.* З. Бигиев. *Газзә түти чәчәкле касә белән Сәйфулла алдына сөзмә дә китереп куйды.* Э. Еники.

2. Чәчәк тажына оя булып хезмәт итә торган, үзара тоташып үскән яшел яфраклар божрасы. *Касәнең түбәнгә бөгелеп торган биш данә яшел яфракчыгы — касә яфракчыклары бар.* Ботаника.

КАСӘМ *и. иск.* Ант. *Мин - - - касәм итеп әйтәмен ки, җәнтимернең* [*жандармның*] *кылычы — кылыч.* Г. Тукай.

◇ **Касәм эчү** — *к.* ант эчү. *Касдсыз кеше касәм эчмәс.* Мәкаль.

КАТ I *и.* 1. Нәрсәнең булса да өстен каплап тора торган әйбер; яссы җисем (саннар яки аергычлардан соң гына кулланыла). *Мирхәйдәр абзыйга өй алдын икенче кат такта белән әйләндереп, ике такта арасына пычкы вагы тутырып, өстәмә бүлмә ясарга туры килде.* Ә. Фәйзи. *Сиражи кышкы суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри - - - торган бер кибетче малай иде.* Г. Камал.

2. Этаж, өйнең яки корылманың аслы-өсле торган бүлемнәре. *Гыймазовлар йортның аскы катында тораллар иде.* С. Рафиков.

3. Мәртәбә, тапкыр. *Җиде кат үлчә, бер кат кис.* Мәкаль. *Мин бу вакыйганың ничек булганын, бер нәрсәсен дә калдырмыйча, баштанаяк, тагын бер кат сөйләп бирдем.* А. Шамов.

КАТ II *и.* 1. Тартым яки килеш кушымчалары белән генә кулланыла: нәрсәнеңдер яны, турысы, аңа якын торган урын. *Шул вакыт мәчет катында дөм сукыр бер карт тора.* Г. Тукай. || Кем дә булса тора торган, яши торган урын, төш. *Кияү - - - кыз катына кич-кич кенә барып йөри.* К. Насыйри. *Атлар катына йөгереп килсәм — атлар юк! Менә агай, йөдәдем бит.* Х. Кәрим. || Кемнең дә булса алды, каршысы. *Гүя син патроннар салып Торасың минем катта.* Ф. Кәрим. — *Авылда эшебез барып чыкмагач, синең катыңа килгән идек.* Г. Иделле.

2. Катында *формасында гына.* Каршында; чагыштырганда, караганда. *Болытның ай катында кадере юк.* Мәкаль. — *Алайса, алар катында безнең мондагы бай хатыннарның киемнәре чүп урынына да тормый торгандыр.* Г. Камал.

КАТА I *и.* Тиз генә киеп алырга уңайлы булган сай һәм җиңелчә аяк кием е. *Өй эченнән иң элек иңенә иске тун, ялан аягына киез ката өстерәгән Сәубан, аның артыннан хатыны Маһибәдәр күренде.* Ф. Хөсни. *Галәк бабай озын ак күлмәк өстеннән җиңсез казаки кигән, аягына каталар әлгән, башында кырпулы бүрек.* Г. Әпсәләмов.

КАТА II *бәйл. диал.* Билгеле бер вакыт мизгеленең, берәмлегенең башыннан ахырынача. *Кыш ката. Көз ката.* □ *Бер урамны өч-дүрт урый, Үзе гармонь уйната. Урам буйлап, гармонь уйнап, Нишләп йөри төн ката?* Ә. Ерикәй.

КАТАЙ *и.* 1. Каты сугышларда бик күп табыш, үлҗә алуы белән мәшһүр булган борынгы (X—XI гасырлардагы) монгол кабиләсе. *Атай малы — катай малы.* Мәкаль.

2. Башкорт кабиләләренең берсе. *Бу авыл Кәртәле исемле кечкенә генә катай авылы иде.* М. Гафури.

КАТАКЛИЗМ *и.* 1. Француз галиме Кювьеның фән тарафыннан инкяр ителгән теориясе буенча: җир тарихында берничә мәртәбә кабатланган гомуми һәлакәт, туфан.

2. *күч.* Кинәттән булган җимергеч ижтимагый хәрәкәт яки көтелмәгән авыр бәла-каза, авыру һ. б. *Тарихи-ижтимагый катаклизмнар.* □ *Тормышның төрле катаклизмнары тудырган бу яшь кешеләргә [зәгыйфь зиһенлеләргә] мастерскойлар --- бирелгән.* А. Гыйләжев.

КАТАКО'МБА *и.* Кешеләр яшеренеп торыр өчен җайлаштырылып казылган җир асты юллары (беренчел мәгънәсе — борынгы Римда христианнарның яшерен гыйбадәт мәгарәсе). *Катакомбаларның, төрмәләрнең Канлы диварлары эчендә Богау тавышлары шалтырый.* һ. Такташ.

КАТАЛА'ЖКА *и. сөйл.* Төрмә, зиндан, хәбесханә. *Гестапо — бу инде сиңа хәрби әсирләр лагере да, полиция каталажкалары да, гади төрмә дә түгел.* Г. Әпсәләмов.

КАТАЛЕ'ПСИЯ *и. мед.* Бөтенләй хәрәкәтсезләнү, теләсә нинди торышта тулысынча катып калу күренеше (кайбер нерв авырулары һәм рухи халәтләр вакытында күзәтелә).

КАТАЛИЗА'ТОР *и.* Химик реакцияне тизләтеп яки акрынайтып, үзе үзгәрешсез кала торган матдә. *Биологик катализаторлар.*

КАТАЛО'Г *и.* Китапларның, картиналарның, музей әйберләренең һ. б. билгеле бер системада төзелгән исемлеге. *Музей экспонатлары каталогы.* □ *Казанда чыккан китапларның университет типографиясендә басылганнары профессор Катанов каталогына кертелгән, бер өлеше академик В. Дорн төзегән исемлеккә теркәлгән.* И. Рәмиев.

КАТАПУ'ЛЬТА *и.* 1. Борынгы халыкларда таш һ. б. ыргыта торган хәрби машина.

2. *тех.* Ыргыту, этеп чыгару механизмы (күп төрле максатларда кулланыла).

КАТАР (катар) *и. иск.* Рәт, саф, тезем. — *Бай баласы булса да, кәнфит суырып үскән байбәтчәләр катарына куярга ярамый аны [Бәширине].* Н. Исәнбәт. || Чират. *Бүркемне салырга өлгерә алмадым, катарга тезеләргә мәҗбүр булдым.* М. Фәйзи.

КАТАР *и.* Эчке органнарның лайлалы тышчалары ялкынсыну авыруы.

КАТАРГЫ *и.* Борынгы зур куш көймә, паром. *Катаргы белән Идел кичү.* □ *Кимә килсә каек качар, катаргы килсә кимә качар.* Мәкаль.

КАТАСТРОФА *и.* Ижтимагый яки шәхси тормышта кискен үзгәрешкә, һәлакәткә китергән гадәттән тыш хәл, вакыйга. *Көнчыгыш фронты катастрофа хәлендә. Бигрәк тә өченче армия участогында.* Х. Садри.

КАТАУ *и. иск.* 1. Балчык стена (там) белән әйләндереп алынган ябулы кура, кутан.

2. Балчык стеналы ныгытма, кальга, кирмән, крепость. *Катауның ике капкасы бар --- капка төпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар иде.* Н. Фәттах.

КАТАФАЛК *и.* Мәетне каберлеккә яки башка берәр җирләү урынына илтү өчен махсус арба яки автомашина. *Карага чорналган мәет арбасы — катафалк тирәсенә путаллы тәреләр төшерелгән киң киемле архиерей һәм әллә ничаклы поплар тезелгән.* М. Гафури.

КАТАШЛЫК *и.* Арыштан башка бөртекле ашлыклар, каты ашлык. *Без арышны үтеп, сабан ашлык басуына килеп чыктык. Каташлык кырындагы солылар шактый агарганнар.* З. Бәшири.

КАТГЫЙ *с.* Кискен, ник карарлы, икеләнүсез, тәвәккәл. *Әсма кинәт вә катгый бер хәрәкәт белән урыныннан торды.* Ф. Әмирхан. || Ташламасыз, каты, аяусыз. *Менә авыл хуҗалыгы уставын бозучылар турында бик катгый карар да чыкты.* Р. Төхфәтуллин. | *рәв. мәгъ. Мондый кешеләргә урамнарга чыгып йөрү катгый тыелды.* М. Гафури. || Хәлиткеч; икеләнүгә, озак уйланырга урын калдырмый торган. *Мостафа Кәмал Россия Советлар власте белән якын сәяси мөнәсәбәт башлауга катгый адымнар атлады.* Ф. Әмирхан. *Катгый сәгать килеп җиткәч, капка төпләрендә городовойлар күренгәч, шәкертләрнең күпчелеге киргә чигенде.* К. Тинчурин.

КАТГЫЙЛЫК *и.* Икеләнүсезлек, карарлылык. *Хәмдиевнең бөтен барлыгыннан, үз-үзен тотышыннан --- катгыйлык һәм җитдилек бөркелеп тора иде.* Р. Төхфәтуллин. || Катылык, килешмәүчәнлек. — *Күрше районда инде өченче көн чәчәләр, — диде вәкил, катгыйлыгын, талэпчәнлеген әз генә дә йомшартмыйча.* Н. Фәттах.

КАТЕГО'РИЯ *и.* 1. *филос.* Чынбарлык күренешләренең иң гомуми сыйфатларын, иң катлаулы мөнәсәбәтләрен чагылдыра торган фәнни, логик төшенчә. *Милләт — социаль-тарихи категория. Ләкин Думави моның бөтенләй киресен расларга тырыша.* Х. Госман. *„Иреклелек“нең нинди философик категория булуын һәм ничегрәк аңласаң дөресрәк буласын әйтергә тырышып караучылар да булды.* И. Гази.

2. Фәнни терминологиядә: тикшерелә торган предметларның төркемен, аларның иң гомуми билгеләрен белдерә торган төшенчә. *Грамматик категорияләр.* □ *Һәрбер фәннең үз категорияләре бар һәм ул шул категорияләр белән эш итә.* М. Абдрахманов.

3. Мәгълүм бер билге буенча бүленеш, классификация. *Һәвәскәр балыкчыларны мин үзем өч категориягә бүләм.* М. Әмир || Төр, сорт; даирә. *Бу әшәкелек [сүгенү] бер категория яшьләр арасында шактый таралган чир бит.* Ә. Еники.

КАТЕЛ *и. иск.* Үтерү күренеше. *Җинаятьчегә кател ясау.*

Кател итү (кылу) — үтерү. *„Зөләйханы кател итмәделәр. Зөләйха үз-үзенә револьвер илә кател итте“.* З. Бигиев. **Кателе гам** *иск.* — *к.* геноцид. *Мәҗит Гафури да [реакция елларында] төркстанлыларга кателе гам ясалган вакыйгалар мөнәсәбәте белән „Бер нәүхә“ исемле шигырен яза.* Х. Госман.

КАТЕР *и.* Якын араларга йөри торган кечерәк судно. *Дулкыннарны ярып катер бара, Якынлаштык каршы як ярга.* С. Урайский. *Кич белән дүрт диңгезче, катерга утырып, култыкның аръягына чыкты.* Г. Әпсәләмов.

КАТЕХИ'ЗИС *и. кит.* Гадәттә сораулар һәм җаваплар формасында булган христиан дине дәреслеге. — *Ишетүемә караганда, катехизис чаклы катехизис та сезне геометрия дәресенә качудан туктата алмаган.* Ж. Тәрҗеманов.

КАТИБӘ *и.кит.* Секретарь хатын-кыз, секретарша. *Конторада дәфтәр тотучы катибәләр тезелеп тормакта.* Р. Фәхретдинов.

КАТИП *и. кит. иск.* Секретарь, язып торучы кеше. *Мәҗлестә Төлке катип, Бүре рәис.* М. Гафури.

КАТИПЛЕК *и. кит. иск.* Катип эше, катип вазифасы. *Катиплеккә Хөсәен сайланды. Моннан соң җәмгыятькә исем бирү мәсьәләсе кузгалды.* Ф. Әмирхан.

КАТКАК *и. диал.* Җир өстендә кибеп каткан балчыклы урын, такыр (1 мәгъ.) *Ишәк әзе каткакта калмый, баткакта кала.* Мәкаль.

КАТКАНАК *с. диал.* Каткан балчыклы. *Гаязны --- катканак урам да, әреле-ваклы өйләр дә, тау битендәге пожар таскагы да --- куанып каршы алдылар.* Х. Сарьян.

КАТ-КАТ *с.* **1.** Күп катлы, күп катламлы, катлы-катлы. *Кат-кат кием.* □ *Каз канаты кат-кат була, Ир канаты ат була.* Җыр. *Аланда күл. Кечкенә, түгәрәк кенә. Кыш бабай боз белән томалап, өстенә кат-кат юрган ябып киткән.* Г. Гобәй. *Өстә кат-кат ямау белән йөргән еллар да әле ерак түгел.* С. Рафиков. || Аслы-өсле. *Бу бүлмәнең ике почмагында зур-зур яшел сандыклар өстенә кат-кат түшәкләр өелгән.* Ә. Фәйзи. | *рәв. мәгъ. Йолдызлар шундый күп, әйтерсең берсе өстенә берсе кат-кат өелешеп беткәннәр.* Г. Әпсәләмов.

2. Күп мәртәбә, берничә кат. *Кат-кат әйтү.* □ *Сафа бабай, кат-кат башымнан сыйпап: — Егетсең, балам, йөзне хур итмәдең, — ди.* Г. Ибраһимов. *Шөпшә бал корты эшләгән савытны кат-кат караган һәм аны бик-бик мактаган.* А. Алиш.

КАТЛАМ *и.* **1.** Кат-кат булып торган нәрсәнең бер каты. *Катлам артлы катлам эри кар, һәр катламның аерым сере бар.* С. Баттал. *Юлга асфальт икенче катлам булып салына иде. Өске катламы тигезрәк.* М. Хәсәнов. || Геологик пласт. *Гранит катламы.* □ *Аз укылган бөек эпос — Бу җирнең катламнары.* М. Сөндекле.

2. *күч. к.* катлау II. *Кайбер кешеләрнең үлүенә Аерым берәр катлам кайгыра.* М. Гафури. *Крестьянның төп катламы бу хәлдән соң, үз эченә йомылып, мыштым гына йөрер булды.* Ә. Фәйзи.

Катлам басымы — билгеле бер җир катламына төшә торган яки шул катламдагы сыеклык, газларны кыса торган басым. *Бу елларда Татарстан нефтьчеләре „кара алтын"ны катлам басымы ярдәмендә чыгаруга күчтеләр.* Ш. Бикчурин.

КАТЛАМА *и.* Өстенә май, шикәр, мәк кебек тәмләткечләр ягып, кат-кат бөкләнгән төче камыр җәймәсеннән пешерелгән ашамлык. *Кичә көлтә кертергә барганда әнкәй кесәмә салган төче катлама хәтеремә килде. Катламадан да тәмле әйбер бар микән дөньяда.* А. Гыйләҗев. *Сажидә тути безне күкәй күмәчләре, бодай катламалары белән сыйлый иде.* Г. Галиев.

КАТЛАМЛЫ *с.* Катламы булган, катламнардан торган, кат-кат. *Кыш көне катламлы болытлар күкне каплаганда, гадәттә болытсыз көннәрдәгедән җылырак була.* Физ. геогр.

КАТЛАНУ *ф.* **1.** Катлар, катламнар тәшкил итү. *Мария Петровна үзе тәбәнәк, үзе артык юан, Ияге ике катланып салынып төшкән.* И. Салахов.

2. Бөгелү, бөгәрләнү. *Очырма туфрагына урам көчеге кебек чумып, өчкә катланып, аркасын җылы мич моржасына терәп, безнең Йосыф йоклап ята.* Г. Гобәй.

КАТЛАУ I *ф.* Ике яки берничә кат итү, кат-кат итү. *Габдулланы баштанаяк киендереп чыгардылар да чанага берничә катлап җәелгән иске юрганнар өстенә утырттылар.* Ә. Фәйзи.

КАТЛАУ II *и.* **1.** Берәр өсйөзгә түшәлеп, җәелеп яткан масса. *Мәулиха түти зур җәймәләр өстендә җылынып яткан бодай катлавын иркәләгәндәй йомшак итеп учы белән тигезли-тигезли әйләнеп чыкты.* Г. Бәширов. || Катлам, геологик пласт. *Кандызның уң ярындагы текә тауларында--- биш-алты метр гына тирәнлектә калын таш катлаулары ята.* Г. Галиев.

2. *җый. и.* Социаль-экономик хәлләре, дөньяга карашлары, культура дәрәҗәләре буенча бериш кешеләр. *Эксплуататор катлауларга халыкның ачуы үсте, халык үз таләпләрен әйтүдә батырайды.* Х. Госман. *Авылның кулак-куштан катлавы мине чит күрә.* Г. Толымбай.

КАТЛАУ-КАТЛАУ *с.* Күп катлаулардан, катламнардан торган. *Трактор җир буйлап сөреп, катлау-катлау кара балчыклы җирне ишеп бара.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Шахтер, тук-тук чукып, катлау-катлау ташны җимерә.* М. Гафури.

КАТЛАУЛАНУ *ф.* **1.** Кат-кат, катлау-катлау булу. *Болытлар катлауланып-катлауланып шәһәр өстенә таба агыла башладылар.* Г. Ибраһимов.

2. Ижтимагый катлауларга аерылу, дифференцияләнү. *Крестьяннар арасында да ризасызлык үскәннән-үсә һәм авылның үз эчендә сыйныфларга катлаулану [бара], шул катлаулар арасындагы дошманлык кыза.* Г. Нигъмәти.

3. Кыенлашу, четереклөнү, киреренке төс алу. *Әсәрдәге [Т. Гыйззәтнең „Кыю кызлар"ындагы] фаҗига тирәнәя һәм катлаулана.* М. Җәлил. *КПСС тарихында Советлар властеның җиңүе кайбер өлкәләрдә катлауланып китүе турында әйтелә.* Г. Кашшаф.

КАТЛАУЛЫ *с.* **1.** Катланган, бөкләнгән. *Катлаулы яулык.*

2. Аерым катлаулардан, катламнардан торган. *Күк йөзен карасу-соры, катлаулы болытлар каплап баралар.* Г. Ибраһимов. [*Җик.*] *Атам минем — Кара тау, Туксан тугыз катлаулы, Анам минем Агыйдел, Туксан тугыз тармаклы.* М. Җәлил.

3. Формасы, төзелеше белән бик четерекле; аерым кисәкләре күп булган, хикмәтле. *Катлаулы механизм. Катлаулы орнамент.*

4. *күч.* Күп аерым өлешләрдән, юнәлешләрдән, бүленешләрдән торган, күп тармаклы, күпьяклы, күпкырлы. *„Яшь йөрәкләр" романының сюжеты артык катлаулы түгел.* Г. Нигъмәти. || Күптөрле вакыйгаларны яки мөнәсәбәтләрне, бәйләнешләрне эченә алган. *Г. Камалның тормыш юлы артык озын булмаса да, аның яшәве бик катлаулы --- чорга туры килде.* М. Гали. *Фәтхи бу бәхәсне озайтуның мәгънәсе юклыкны аңлады: — Хосусый милек мәсьәләсе — кечкенә мәсьәлә түгел, бик катлаулы мәсьәлә, иптәшләр.* Ш. Камал.

5. *күч.* Аңлау, чишү, хәл итү кыен булган; четерекле, мәшәкатьле, авыр. *Самовар вакыйгасы никадәр кызыклы булса, менә хәзер аңарда су кайнату шулкадәр катлаулы булды.* Ә. Фәйзи. *Старшина Мәҗитов катлаулы хәлдә дә оста җитәкчелек итте.* А. Әхмәт. *Каршыбызда чиксез зур, чиксез җаваплы,*

житди, катлаулы бурычлар торганын күрдек без. М. Әмир.

Катлаулы хезмәт — озак хәзерлек һәм күп белем, күп күнекмә таләп итә торган хезмәт. *Социалистик хуҗалыкта катлаулы [квалификацияле] хезмәт белән гади хезмәт арасында аерма бар һәм катлаулы хезмәт гади хезмәткә чагыштырып исәпләнә.* Политэкономия.

КАТЛАУЛЫЛАНУ *сир. ф.* Катлаулы булып китү, катлалану.

КАТЛАУЛЫК *сир. и. к.* катлаулылык. *Чынбарлыкны бөтен катлаулыгында аңлауның әһәмиятен бик ачык күрергә мөмкин.* Н. Юзиев.

КАТЛАУЛЫЛЫК *и.* Катлаулы булу сыйфаты. *[Татар әдәби теле] гасырлар буенча үсеп, шактый катлаулылыкка ирешкән.* В. Хангилдин.

КАТЛАУСЫЗ *с.* Катлаулардан тормый торган, тоташ. *Рәмиевләр --- массага үпкәләргә, аны сүгәргә тотыналар. Д бу массаның катлаусыз бернәрсә генә булмаганын, аның сыйныфларга аерылганын аңламыйлар.* Г. Нигъмәти. || Гади, садә, жинел аңлаешлы. *[Гайфулланың] көрәш чаралары зәгыйфь һәм катлаусыз.* М. Җәлил.

КАТЛАУСЫЗЛЫК *и.* Гадилек, садәлек; эчкерсезлек, самимилек. *Дөньяда гел мавыгу белән яшәүче бу сөйкемле карт үзенең катлаусызлыгы белән бөтен кешеләрне үзенә караткан иде.* Ф. Хөсни.

КАТЛЫ-КАТЛЫ *с.* Күп катлы, күп катламлы. *Болытлар, катлы-катлы булып, бөтен күк йөзен басып киләләр.* М. Гафури. *Текә ярлар пычак белән телеп төшергән төсле. Җир кабыгы катлы-катлы.* Г. Ахунов. *Шаулап чыга нефть ташкыннары Катлы-катлы ташлар арасыннан.* Н. Дәүли.

КАТМАР(ЛЫ): катмар(лы) чәчәк — таҗ яфракчыклары катлы-катлы булган чәчәк турында. *Кәҗә бәтие тал гөлен яратты, аның кызыл, сары, ак һәм ал төстәге катмарлы чәчәкләрен чүплап чыкты.* Г. Мөхәммәтшин.

КАТНАР *и. диал.* Түшәмнең өске ягы, туфракса белән кыек арасы, очырма. *Стеклография шул Федька торган тимер юл эшчесе, паровоз слесареның катнарына (өй түбәсенә) китерелеп, прокламация бик күп итеп басылды.* Т. Госман.

КАТНАУ *ф. диал.* Ишелгән бауны юанайту яки тукылган, үрелгән нәрсәне калынайту өчен, җеп яки тасма өстәп тукып, үреп чыгу, кат өстәү. *Солтангәрәй, билгеле, чабата катнау белән генә чикләнмәде, вакыт булганда хуҗалык эшләренә дә булышты.* Ш. Еникеев.

КАТНАШ I *и.* **1.** Берәр эштә, вакыйгада башкалар белән бергә күрсәтелгән эшчәнлек, ярдәм, булышлык. *Татар операсының тууында, татар музыка-театр көчләреннән тыш, рус һәм башка халык белгечләренең катнашы булган.* М. Җәлил. *Идарәнең актив катнашы белән узган бу авторитетлы утырыш нәкъ икө пунктта председатель әйткән белән килешмәде.* Ф. Хөсни. *Карелиядә артиллерия һәм авиация катнашы белән киң күләмдә сугыш операцияләрен җәелдерү өчен мәйданнар да бик аз.* Г. Әпсәләмов. || *к.* катнашлык. *[Рәхимә:] Бу телеграммада геолог Нарскийның катнашы юкмы икән?* А. Әхмәт.

2. *сир.* Аралашу, йөрешү, үзара багланыш. *Ике коданың катнашы күп, сыйлары уртак, уен көлкеләре бергә бара.* Г. Ибраһимов.

КАТНАШ II *с.* **1.** Билгеле бер нәрсәнең берничә төреннән яки төрле элементлардан, компонентлардан торган, составы катлаулы булган, төрле нәрсәләр бергә аралашып кушылган. *Катнаш токымнар. Катнаш масса. Катнаш команда.* □ *Катнаш урманнарда имән, өрәңге, карама үсә.* СССР физ. геогр.

2. *бәйл. мәгъ.* Белән, бергә, аралаш. *Каен катнаш нарат урманы.* □ *Чыкырдап торган таш катнаш балчыкларны тимер иләкнең бер ягыннан икенче ягына йөгертәбез.* М. Гафури. || Белән бер үк вакытта. *Тәэкирә, анасына гажәпләнү катнаш аптырау белән карап, үзеннән-үзе кызарып калды.* Ф. Хөсни. *Нәфисәнең йөзендә гажәпләнү катнаш тирән борчылу күренде.* Г. Бәширов.

Катнаш кушма җөмлә — иярченле һәм тезмә җөмләләрдән торган кушма җөмлә. **Катнаш сан** *мат.* — бөтен һәм кисәкләрдән торган сан.

КАТНАШЛЫК *и.* Мөнәсәбәт, кагылыш. *Нәгыйм монда әйтелгән бөтен сүзләргә катнашлык күрсәтүдән төбендә бер генә теләк күзәтә.* Ш. Камал.

КАТНАШМА *и.* **1.** Ике яки берничә төр катнаштырылып ясалган масса, беришле матдә. *Кызыл балчык, су, тирес-салам катнашмасыннан кирпеч өчен яраклы балчык изәргә кирәк.* Н. Фәттах. || Ике яки берничә культура (сорт) катыштырудан барлыкка килгән ашлык, иген һ. б. *Вика-солы катнашмасы, дөрестән дә, ишелеп уңган һәм ул җиренә сыймыйча утыра.* Г. Галиев.

2. Төп массага өстәмә булып катышкан нәрсә. *Балавыз чималында саф балавыз да һәм башка төрле матдәләр катнашмасы да була.* Умартачылык.

КАТНАШУ *ф.* Берәр вакыйгада, шөгыльдә башкалар белән бергә эшлеклелек күрсәтү. *Һажәр сүзгә катнашмады, үз эченнән ничек, ни белән ярдәм итим икән, дип уйлады.* Г. Ибраһимов. *Арада утыз тугызынчы-кырыгынчы ел сугышларында катнашкан егетләр дә бар иде.* Г. Әпсәләмов. *Бу картинада катнашалар: Сәгыйдә Янгуразова, Рәхим Нуруллин, Әхәт Янгуразов.* Һ. Такташ. || Аралашу, бергә күшылу, иш булу. *Ул арада Госман карт башка шахтерлар арасында катнашып китте.* Ш. Камал.

КАТНАШЧЫ *и.* Берәр коллектив эштә катнашкан кеше. *Аларның [анархистларның] тактикасы пролетарийларны буржуаз политиканың пассив катнашчыларына әверелдерә.* В. И. Ленин.

КАТНАШЧЫЛЫК *и.* Катнашчы булу. *Катнашчылык итү.*

КАТОД *и.* Тискәре зарядлы электрод (анодның киресе). *Гальваник элементлар, анод һәм катод арасындагы ионнар хәрәкәте турында Рушад татарча ярды да салды.* М. Мәһдиев.

КАТОК I. *и.* Тимераякта шуу өчен тигез боз белән капланган махсус мәйдан; шугалак. *Катокның шомалыгы гына түгел, бу сәгатьләрдә аңа керергә ярамау да Фәритне аеруча кызыктыра.* А. Шамов. *Куышабыз, Узышабыз, Саф һавада — катокта.* Ж. Тәрҗеманов.

КАТОК II *и.* **1.** Үз авырлыгы белән асфальтлы, комлы, ташлы мәйданнарны тигезли торган авыр тәгәрмәч яки шундый тәгәрмәчле үзйөрешле машина. *Киң табанлы зур катоклар, Тәгәрәп алга-артка, Урам өстен шомарттылар, Асфальты кайнар чакта.* Ш. Маннур. || Сөрелгән туфракның кантарларын бетерү һәм тыгызлау өчен кулланыла торган киң көпчәк рәвешендәге тагылма инвентарь.

2. *техн. к.* ролик. *Каяндыр тасма транспортер табып, аның катокларын файдаланып, пилорамалар астына бүрәнәләр бирүне механикалаштырдылар.* М. Хәсәнов.

КАТОКЛАУ *ф.* Катоклар белән мәйданнарны тигезләү; сөрелгән җирне бастырып тыгызлау.

КАТОЛИК I *с.* Католицизмга мөнәсәбәтле. *Католик дин. Католик чиркәү.*

КАТОЛИК II *и.* Католик диндәге кеше, католицизм тарафдары. *Католикларның нинди дер бер бәй-*

рәмнәрендә төрмәдәге тоткыннарга бүләк-күчтәнәч өләшкәннәр. Г. Кашшаф.

КАТОЛИЦИЗМ *и.* Христианлыкның башында Рим папасы торган көнбатыш мәзһәбе.

КА'ТОРГА *и.* Тоткынлыкта һәм аеруча авыр шартларда эшләтү белән бәйләнгән җәза; шундый җәзага дучар булган тоткыннарның мәҗбүри эш урыны. *Әткәй коткарам дип йөри торгач, актык атыннан, сыерыннан яза, абыйны егерме елга каторгага хөкем итәләр.* Г. Ибраһимов.

КАТОРЖАН *и. сөйл. к.* каторжник. *Анда богауланган каторжаннар әле дә күз алдымда тораләр.* М. Гафури.

КА'ТОРЖНИК *и.* Каторгага, сөргенгә хөкем ителгән яки шунда булып кайткан кеше. [*Зариф:*] *Әллә мин каторжникмы, җимерелеп эшләргә?* Ш. Камал. || *гади с.* Җинаятьчел, әдәпсез, законга каршы эшләр эшләүче кеше. *Җыен каторжник шул Заболотноега барып оялый башлады.* К. Нәҗми.

КАТР *и. сөйл. к.* каторга. *Һәр җирдә крестьяннар алпавытларны талыйлар, шуның өчен крестьяннарны бишәрләп-унарлап асалар, Себергә, катрга озатып тораләр, ди.* М. Гали.

◇ **Катр китү** — сөргенгә җибәрелү. [*Айсылу:*] *Нинди җир соң ул? Әнә теге караклар катр китә торган Себер ягы түгелме соң ул?* Н. Исәнбәт.

КАТРӘ *и. иск.* Тамчы. *Аракының катрәсе каннан яман.* Мәкаль. *„Дин дошманнары" булган поп белән мулла янәшә торып, нигә болай катрә кан калганчы әллә кемнәрнең милекләрен сакларга ант иттерәләр?* М. Гафури.

◇ **Катрә бөртек (катрә бөртеге) кадәр** — бик аз гына. — *Йа-а, катрә бөртеге кадәр дә кешелегең юк икән, — диде Мортаза.* М. Хәсәнов.

КАТУ I *ф.* **1.** Каты хәлгә килү. *Өстәл өстендә бер кыерчык каткан күмәч белән бер стакан тора.* Г. Камал.

2. Туңу, суыну нәтиҗәсендә яки түбән температура тәэсирендә каты хәлгә килү (сыеклыклар турында). *Кичке салкын белән аяк асты ката башлаган, артык пычрак түгел.* Ш. Камал. *Агыйделнең агым җире Кыш булса да катмыйдыр.* Җыр.

3. *күч.* Өшү, күшегү. *Болай да суыкка катып, өшеп кергән малай кычкырып еларга ук тотынды.* М. Гали. *Кул-аяклар катты, без суыктан җилек кипкән төсле суырылдык.* М. Җәлил.

4. Ябышып кибү, ябышып каплау. *Баш, муен, җилкәләр тирләп, аларга тузан каткан.* М. Гафури. *Өйдәге балалар, тәрәзәгә каткан бозны шул арада инде сулышлары белән шактый эретеп тә өлгерделәр.* А. Алиш. || *Юнәлеш килеш белән.* Нәрсәгә булса да буялу, пычрану. — *И, кыл муен, шул тирескә каткан көрәген кызганган була.* И. Гази.

5. Керләнү, пычрану; тупаслану. *Каткан күлмәк. Каткан идән.* □ *Кайберләре тыштан котелок белән алып кергән карны эретеп, каткан битләрен, кулларын да юып алдылар.* М. Гали.

6. Хәрәкәтсезләнү, үзгәрешсез хәлдә калу. *Госман катып тик тора, ник кенә бер сүз әйтсен.* Ф. Хөсни. *Кыз әйләнеп карады да баскан җирендә хәйран булып катып калды: аның каршысында үзенең ахирәте Чулпан иде.* Г. Ибраһимов. || Берәр нәрсәгә әверелеп, хәрәкәтсез калу. *Тора һәйкәл ядкәр булып батырларга, Җизгә катып баһадирлык ныклыклары.* Ш. Мөдәррис. *Килде кырыс төннәрең — Кантарланып катты юл.* З. Нури.

7. *күч.* Ваемсызлану; усаллану; хиссезләнү. *Күңел кату* □. *Мәдинә гарьлегеннән буылып еларга телән карады. Тик булдыра алмады. Бәгырь дигән нәрсә тәмам каткан иде.* М. Хәсәнов.

8. *туп.* Үлү, дөмегү. *Фәхри бабай, Галимә апаның нәкъ өстенә карап: — Илаһем, шул ятkан урыныңда кат!.. — дип әйтте дә, ишекне шап иттереп ябып, чыгып китте.* М. Гафури. *Шәмсетдин хәзрәт агу эчеп катарга өлгергән.* Э. Касыймов.

КАТУ II *и.* **1.** Кызу йөргәндә яки йөгергәндә кинәт авырттырып сулыш кысылу, тын бетү күренеше (сулыш аппаратының зәгыйфьлеге яки берәр авыру нәтиҗәсендә була). *Эчне кату алу. Кату тыгылу.* □ *Без йөгереп барабыз, шулай да җитешеп булмый. Кайсыларыбызның әүләренә кату чыгып бетте.* Г. Лотфи. || Шул күренешне тудыра торган берәр төрле авыру (мәс. бүсер). — *Минем эчтә кату бар, походка ярамыйм.* Т. Гыйззәт. *Тын алып булмый да шабаш. Кату... Минем әнине дә шул кату гүргә алып китте.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. *күч.* Әкренләп жыела килгән пошыну, кайгы яки ачу хисе. *Җаны аеруча газапланa башлагач, эченә кату булып җыелган серләрен уртаклашу өчен дип, бер көнне ул [Мөнәвәрә] әниләренә барып утырды.* Г. Ахунов. *Юк, бу сөю көнчелеге түгел, ә йөрәккә утырган шәфкатьсез ачу катуларының ишелүе генә.* А. Шамов. *Күкрәп үскән күкрәгемдә Хәсрәт катулары бар.* Җыр.

КАТУ III *ф.* **1.** Кушу, кушылдыру; аралаштырып болгату; бутау. *Ярар безгә — майлы күзгә әйрән каткан ботка да.* Мәкаль. *Әй, катык каткан борай Токмачлы шулпа пешсәче!* И. Думави. *Куйдылар инде шикәр каткан җылы сөтне аңар [песигә].* Г. Тукай.

2. Ике яки берничә җепне (яки бау җәбен) бергә кушып бөтерү, ишеп бер җеп (бау, киндерә) ясау. *Катылган ефәк.* □ *Өстәл тирәсенә тезелеп җиде авыл хатыны, баш авыл кызы утырганнар. Кайсы җеп эрли, кайсы ката.* М. Фәйзи.

3. Кем белән дә булса аралашырга теләк белдерү; шуның хәленә керү (аерым тезмәләр составында). *Сүз кату.* □ *Ярлыга якты чырай катсаң, ямаулык сорый.* Мәкаль.

КАТУ IV *ф.* **1.** Ялгау, дәвамын өстәү. *Көнне төннәргә катып син эшләсәң дә һәр заман, Ярты тиенлек файда итмисең, ялангач син һаман.* М. Гафури.

2. Үткәрү, уздыру (вакыт турында). *Юлдашың яман булса — Ерак йөреп төн катма.* Мәкаль.,

КАТУ'ШКА *и.* Бау сыман әйберләр (тимерчыбык, шнур һ. б.) уратыла торган махсус цилиндр, зур шүре. *Аркасына катушка аскан бер әлемтәче тирләп-пешеп килеп җитте.* Г. Әпсәләмов. *Арба күчәре кебек зур-зур катушкаларга чорналган тимерчыбыклар --- янында Борһан ага йөренеп тора.* Р. Төхфәтуллин.

КАТЫ *с.* **1.** Физик җисемнәр турында: газ һәм сыеклыклардан үзгә буларак, гадәттәге шартларда үз формасын, күләмен саклый ала торган. *Каты әйберләр ике төрле булалар: кристалл һәм аморф әйберләр.* Физика.

2. Яньчүгә, кисүгә, сузуга һ. б. деформацияләргә зур каршылык күрсәтә торган. *Каты таш. Каты металл.* □ *Каты агачка каты чөй!* Әйтем. *Нинди-дер каты токым бурны кире этәрә, бәреп чыгарырга теләгәндәй сиртмәләндерә.* Ә. Айдар. *Ызандагы каты камылларга, карт үләннәргә сыдырылып [егетләрнең] битләре тырналып беткән.* А. Шамов. || Нык, көчле; бирешми торган. *Каты муенлы алашам--- миңа баш бирмичә чабып китте.* Ш. Маннур. *Минем янга яңадан ике малай йөгереп килделәр. Икенчесе белән алыша башладык. Бик каты билле икән, бер дә алыр әмәл юк.* М. Гали.

3. Билгеле бер тәэсиргә бирешми торган. *Таш каты, таштан бигрәк баш каты* [сүз аңлатып булмый]. Мәкаль.

4. *күч.* Кырыс, катгый. *Каты боерык. Каты җавап.* □ *Шәһәр советына җитәкчелек итү өчен, бигрәк тә мондый чорда, нык куллы, каты кеше булырга кирәк.* М. Әмир. *Нурмөхәммәт каты холыклы крестьян иде, баласының болай оятсызлануына чыдамады.* Г. Ибраһимов. || Шәфкатьсез, аяусыз. *Үз-үзеңне хөкем итүдән дә авыр һәм каты хөкем юк.* А. Шамов. *Каты көрәш белән җавап бирде Татар халкы каты изүгә.* Ә. Ерикәй. | *рәв. мәгъ. Каты сөйләшү. Каты әйтү. Каты кылану.* || Газаплы, авыр, кыенлыклы. *Каты кайгы. Каты сугыш. Каты суык.* □ *Юллар, юллар, сез бит барыгыз да Менә шундый каты, аяусыз.* М. Җәлил. *Алты-җиде яшендә Бакый чәчәк белән авырды. Авыруы бик каты булды.* Г. Әпсәләмов. | *рәв. мәгъ. Сәләхи бик каты яраланган.* Ш. Камал. || Көчле, киеренке. *Каты ачу. Каты буран. Каты тавыш.* □ *Каяндыр, кинәт кенә каты җил чыкты.* Г. Бәширов. *Ягъни, хәрби тел белән әйтсәк, кинәт каты удар ясап, дошманны Николаево авылыннан бәреп чыгарырга.* И. Гази. *Танылның каты агымлы сулары үзләре белән күп кенә корбаннарны алып киттеләр.* М. Шабай. || Бик нык сизелеп торган, көчле дәрәҗәдәге. *Паларусов каты чуваш акценты белән кабатлады.* Г. Ибраһимов.

5. Тәме нык беленә торган, организмга тәэсире көчле булган (чәй, тәмәке һ. б. турында). *Шундый кара, каты тәмәкене, юан итеп төреп, секретарь гына тарта.* А. Шамов. *дсман карт--- Соңгы елларда җылы төр һәм каты чәй яратучы бабайлар җөмләсеннән исәпләнә иде.* М. Әмир.

6. Үзендә тозлар күп эрегән (минераль тозларга бай су, сыеклык турында). *Кар суы каты булмас, кыз кебек хатын булмас* [*„хатынлыкка кыз алырга кирәк“ мәгънәсендә*]. Мәкаль.

7. Тирән, тиз генә уянмаслык (йокы турында). *Нишләп болай каты була икән Таң алдының татлы йокысы?* Ш. Маннур. | *рәв. мәгъ. Кичә эштән арып кайткан ирләр, Ял көне икәнен белгәнгә күрә, бүген каты һәм озак йоклыйлар.* Г. Мөхәммәтшин.

8. *и. мәгъ.* Каты җир, каты урын; каты өлеш. *Катыга бәрелеп, азрак тез башы яңгыраган булса да, белгертмәдем.* М. Гали. *Шул төнге тавышларга бераздан юл катысына тук-тук шакылдаткан таяк тавышы кушылды.* Ш. Еникеев. *Ипи катысыз пешми.* Мәкаль.

9. *рәв. мәгъ.* Нык итеп, тоярлык итеп. *Тс-с-с!—диде сестра һәм терсәге белән Хәлимгә каты гына төртте.* А. Шамов. *Барабыз алга табан каты басып, Тетрәсен дошманнарның йөрәкләре.* М. Гафури. || Бик нык, шәп, үтә. *Юк, энекәем, дөньяның кендеге синең кулда дип уйласаң, син каты ялгышасың.* А. Гыйләҗев. — *Ай-яй, каты тоткансың да икән гыйшыкны!* Г. Бәширов. || Көчәнеп, көч белән. *Бик каты тартышу.* □ *Бик каты сузсаң, җеп тә өзелә бит.* Г. Ибраһимов. || Шәп, җитез, тиз. *Ат ни арададыр сыртка менеп тә җитте, тагы да катырак чабып, үрдән төшә башлады.* А. Расих.

Каты билчән — билчәннең бик биек үсә торган бер төрчәсе, аксыл шәмәхә чәчәк ата. **Каты бүрек** *иск.* — цилиндр сыман тигез түбәле биек эшләпә. *Тарантаста башына каты бүрек киеп утырган бер бай баласы.* Г. Газиз. **Каты корт** — шыртлавык коңгыз личинкасы — буынтыклы, озынча сары корт (тиресле һәм көпшәк туфракта очрый). **Каты пешү** — озак кайнатылып (кыздырылып) пешү. *Каты пешкән күкәй Маратның авыз суларын китерде.* Г. Гобәй. **Каты сабан (сука)** — 1) парга сөрү (көзгә таба). *Җәйнең уртасы килеп җитте. Халык бик кызуланып каты сукага хәзерләнә.* Ш. Әхмәдиев. — *Балдыз, каты сабаныңны бу юлы мин сөрә алмыйм.* К. Тинчурин; 2) парга сөрү җире. *Өем-өем тирес каты сукага чыгарып түгелгән дә, инде сукаланган.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Каты таракан** — тирес коңгызының бер кечерәк төре. *Син ат тизгеннән корт эзлисең, каты таракан нәселеннән түгелсең ләбаса.* Ф. Хөсни. **Каты тула, каты чикмән** — каты җеп кушып, бик тыгыз тукылган тула һәм шуннан тегелгән чикмән. *Җәмиләнең өстендә тигезле-тигезсез йорт туласыннан эшләнгән каты чикмән иде.* К. Басыйров. **Каты юкә** — каезланган, телемләнгән, ләкин җебетелеп аерым катламнарга аерылмаган юкә кабыгы. *Каты юкәдән илək үргә, аны кысага беркетергә кирәк.* Г. Галиев. **Каты ягулык** — ташкүмер, утын, торф кебек ягулыклар.

◇ **Каты бавырлы (бәгырьле)** — каты күнелле, кызганмаучан, шәфкатьсез. *Биремҗан карт каты бавырлы, аз акыллы бер чал.* Г. Ибраһимов. [*Абдул*] *хатынының каты бәгырьле икәнлегеннән зарланып алды.* С. Рафиков. **Каты борын** *әвф.* — дүнгыз, чучка. *Кайбер кешеләр „каты борын“ дип йөртә торган симез-симез дуңгызлар да күп бездә.* А. Әхмәт. **Каты бәрелү** — кискен һәм тупас сөйләшү яки мөгамәлә итү. *Фәгыйлә Мөстәкыйм бабайга каты бәрелмәскә тырышып килде.* М. Әмир. **Каты кул белән** — ныклы, ышанычлы итеп. — *Әле ярый, каты кул белән бәйләгәнсең, таралып китмәде.* Ф. Хөсни. **Каты куллы** — 1) авыр эшләрне булдыра ала торган. *Үги әнәй җен күк эшли безнең. Теләсә нинди эшкә шундый каты куллы, шундый җитез ул — аңа ни җитте кеше тиңләшә торган түгел.* Ш. Маннур; 2) кырыс мөгамәләле, талəпчән. *Нурый карт каты куллы, саран мужиклардан санала.* Г. Ибраһимов. **Каты куллылык** — кырыслык, җәза бирүчәнлек. *Пәрхулла абзыйның тәүфыйгы — инсафы дисәң — ике муллага җитәрлек. Каты куллылык дисәң — малайларыннан сорагыз.* Ш. Маннур. **Каты әйтү** — көчле тәэсир итәрлек итеп, шелтәле яки ачулы сүз әйтү. [*Илдарга*] *Гөлсем апа бик каты әйтте, җелегенә үтәрлек итеп.* Г. Гобәй. **Каты өн** — катгый һәм тупас кыланыш, мөгамәлә тәэсире. *Аның* [*үги ананың*] *мәрхәмәтле булып күренергә тырышуларында ук бер ясалма куштанлык бар, бу ясалма куштанлыкның каты өне балаларны һәрвакыт өркетеп тора иде.* Ф. Хөсни.

КАТЫЙЛЬ *и. кит. иск. к.* палач. *Намуслы катыйль дә була, намуссыз хәким дә була.* Мәкаль. *Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда, Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә, Кирәк икән, үләм аягүрә, Балта белән башым киссәң дә.* М. Җәлил.

КАТЫК *и.* Оеткы салып, махсус әчетелгән, оетылган сөт. — [*Бозауларның эч китүенә*] *әчеткән сөт килешә дип ишеткәнем бар иде, туктале, мин әйтәм, катык ничегрәк булыр икән, дим. Катыкны да бит сөттән оетабыз.* Ә. Еники.

КАТЫКЛЫ *с.* Катык катылган (аш турында). *Малайлар әниләренең катыклы салмаларын ашарга кайтып киттеләр.* Л. Ихсанова.

КАТЫ-КОТЫ. *җыйм. и.* Каткан, кипкән, каксыган камыр ашамлыклары. — *Каты-коты белән туклану.* □ *Габдулла, каты-коты белән тамак ялгап, Сәлүк белән чәй эчеп алганнан соң, сәндерәгә менеп ятты.* Ә. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Каты, коры, киптерелгән (ашамлыклар турында). *Айдар, кулындагы күчтәнәчләрен ишектән керүгә әнисенә биреп, өстәде: — Каты-коты нәрсә шунда. Туры килгәч алдым, җебетеп ашарсыз.* Ф. Хөсни.

КАТЫК-СӨТ *җыйм. и.* Сөт һәм сөттән хәзерләнгән төрле ашамлыклар. *Уникe семьяга — унбер сыер---*

катык-сөт җитә. Ш. Камал. — *Әнинең шифалы катык-сөте белән бераз юньгә кереп булмасмы, дип кенә кайттым.* Р. Төхфәтуллин.

КАТЫЛАНУ *ф.* Каты (1—4 мәгъ.) булып китү, каты хәлгә килү. *Юл катылану. Күңел катылану.* □ *Хөсәеннең туктаусыз тәмәке тартудан тамагы карлыкты, тавышы катыланды.* Г. Мөхәммәтшин.

КАТЫЛЫК *и.* 1. Каты булу. *Металл катылыгы.*

2. Катгыйлык, каты тору. *Иркенлек боза, катылык төзә.* Мәкальләр. || Кырыслык, рәхимсезлек. *Күрше белән борыннан Булмады һич татулык: Көн саен бер усаллык, Көн саен бер катылык.* М. Җәлил. || Тупаслык, васыйсызлык. *Җанның катылыгы харап итә безне.* Ә. Фәйзи.

3. Тәме яки тәэсире көчле булу (чәй, тәмәке һ. б. турында). *Белмим, әллә чәй катылыгыннан, әллә томан күелыгыннан, башым әйләнде.* Э. Касыймов.

КАТЫНША *и. сөйл.* 1. Вакчыл, хатын-кызлар эшенә тыгылучан ир кеше; *к.* Хатынша. *Катыншадан хатын артык.* Мәкаль. *Ирдәүкә булса — хатының яу, Катынша булса — ирең яу.* Мәкаль.

2. *с. мәгъ.* Ычкынырлык итеп төйнәлгән. *Төенең катынша булмасын, нык булсын.* А. Гыйләжев.

КАТЫНШАЛАНУ *ф. сөйл.* Катынша (1. мәгъ.) булып китү; катыншалык күрсәтү. — *Йөрмәле монда катыншаланып, --- сиңнән башка да өйрәтүчеләр җитәрлек.* Н. Фәттах.

КАТЫНШАЛЫК *и. сөйл.* Катынша холыклы булу сыйфаты, вакчыллык. *Сакалның бер тотамнан озын булуы ахмаклык, бөтенләй кыска булуы катыншалык галәмәте.* Н. Исәнбәт.

КАТЫР: катыр туфрак — бик күп натрий сендергән, дымланса катып китә торган туфрак. *Катыр туфракларны гипслагач, ягъни туфракка гипс керткәч, андагы зарарлы натрий элементы сульфат кислотасының натрий тозына әверелә һәм суда эреп, туфрактан юыла.* Химияне а. х. куллану.

КАТЫРГАН *и. диал. к.* крыжовник. — *Син миңа бер-ике бөртек катырган җимеше өзеп бир. Җиде төп катырган куагы булырга тиеш бу бакчада.* М. Әмир.

КАТЫРГЫ *и.* Калын, каты кәгазь; картон. *Бу кеше казаки якасы эченнән катыргы куйган иде.* Ф. Әмирхан. || Катыргыдан торган, катыргыдан эшләнгән төрле әйберләр, детальләр. *Козырек катыргысы.* □ *Башына катыргысыз рус картузы, аягына искергән кәвеш, җилкәсенә тапланып беткән пиджак салып чыгучы кеше шәкерт Гыйззәт иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. || *с. мәгъ.* Катыргыдан эшләнгән. *Катыргы тартма. Катыргы футляр.* □ *Фәридә вожатыйга катыргы тышлы бер зур китап сузды.* А. Әхмәт.

КАТЫР-КОТЫР *аваз. иярт.* Каты азыкларны ачык ишетелерлек аваз чыгарып чәйнәү, кимерү тавышын белдерә. *Арпа бирсәң, атка бир — Катыр-котыр чәйнәсен.* Мәкаль.

КАТЫРУ *ф.* 1. Катыландыру, каты, киренке хәлгә китерү. *Ул [музыкант] артка чигенеп-чигенеп китә дә күкрәген киереп, мускулларын катырып, тагын клавишалар өстенә ташлана.* Ф. Кәрим. *Ул [төлке], мамык койрыгын уктай катырып, бер аягын күтәреп, муенын сузып беравык хәрәкәтсез торды.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Туңдыру. *Миңнәхмәтләргә сылтар өчен, кулаклар әлеге үзләрендә саклана торган берничә корт илән юри катырып үтерәләр.* Г. Толымбай. *Кышның язга каршы кисәк кенә катырып җибәргән чагы иде.* М. Шабай. *Аяк асты нык катырмаган, һава болытлы, җепшек.* Ш. Камал.

3. Чыг. яки юн. килеш белән килгәндә: берәр әретмәдән коеп яки берәр ябыштыручан сыеклык, измә ярдәмендә ныклы предметлар, корылмалар ясау. *Бишун минут үттеме икән, җил дә кермәслек итеп кирпечтән-таштан катырган лапас астында, шул ук ике кеше — ата һәм аның кызы — басып калды.* Ф. Хөсни. *Бериш кешеләр хыял диңгезендә йөзеп әллә нәрсәләр күз алларына китерәләр: мәрмәр сарайлар, прәннектән катырган йортлар, шоколад капкалар.* А. Гыйләжев.

КАТЫШ I *с.* 1. Нәрсә белән дә булса аралашкан, бергә буталган. *Тәрәзә төбендә дәва шешәләре күренә, шулардан булырга кирәк, тәмәке исе белән катыш авыр исләр аңкый.* Ш. Камал. *Китап укыганда әни бик нык тәэсирләнеп, йөзендә курку белән өмет катыш галәмәтләр чыга торган иде.* М. Гафури.

2. *сир.* Шикле, тынычсыз; вәсвәсәле, гасаби. *Аның [Зыяның] вәгъдәле көннән кичегүе Зөләйха абыстайда әллә нинди катыш хиссият уятты.* Г. Ибраһимов. *Бары тавышының гадәттәгедән катырак һәм әллә ничек катышрак чыгуы аның [Лизаның] яшерергә теләгән нәрсәсен ачык күрсәтә иде.* Ф. Әмирхан.

3. *и. мәгъ. диал. к.* катнаш I. 1. *Катышлыга катышың булмасын.* Мәкаль. — *Эш бар икән, синең катышың шуның хәтле, җаный.* С. Рафиков.

КАТЫШ II *бәйл.* 1. Аергысыз бергә аралашкан булуны белдерә. *Май аенда кар катыш яңгырлар явып торды.* М. Әмир. — *Я, булдыңмы? — дип шатлык катыш кызыксыну белән сорау бирде Җаббар.* Ә. Фәйзи.

2. *сир.* Берәттән, аралаш. *Бераз халык [хәмер саткан кибет янында] Торалар урыс белән татар катыш.* М. Гафури.

КАТЫШЛЫ *с. диал.* Дуамал, каудар. *Мөнәвәрә иренең муеныннан кочып алды. — И сине, катышлы. Хәзер дулап китәргә генә тора.* А. Расих.

КАТЫШТЫРУ *ф.* 1. Катнаштыру. *Спектакльгә --- кызлар катыштыру хакындагы һәрбер тәшәббесебез нәтиҗәсез калды.* М. Фәйзи.

2. Кирәкмәгән нәрсәне китереп кушу, берәр нәрсәне урынсыз куллану. *Катыштырма вә ләкин телгә телне, Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.* Дәрдмәнд.

КАТЫШУ *ф.* 1. Бергә аралашу, бергә буталу, кушылу. *Катышты алтын-көмеш бакыр-җизгә, Бер сурәттә күренделәр болар күзгә.* М. Гафури. || Килеп кушылу. *Әбиемне ышык кына, тыныч кына, уңайлы гына бер җиргә утыртып, үзем йөрүчеләр арасына катышып киттем.* Ф. Әмирхан. || Катнашу. *Әңгәмәгә безнең әти дә катышкалый.* Ш. Маннур.

2. Аралашу, күрешү-йөрешү, алышу-бирешү. *Фәхри бик яшьтән үк бу йортка катышты, үзе калада торса да, Гәрәй мирзаларга килеп-китеп йөри иде.* Г. Ибраһимов.

3. Кысылу, тыгылу, читтән килеп катнашу. — *Карагыз, сез дә анда сайлау эшләренә катыша күрмәгез.* Ш. Мөхәммәдев.

КАТЮША *и. сөйл.* Реактив миномётның шаяртып әйтелә торган атамасы. *[Башкомандующий] безгә ярдәмгә танклар, үзйөрешле артиллерия полкы, „катюшалар" җибәргән.* Г. Әпсәләмов.

КАУ *и. диал.* 1. Чакма белән ут кабызу өчен кулланыла торган махсус киптерелгән гөмбә, мәшкә, ку. *Чакма чакмый кау янмый.* Мәкаль.

2. *к.* каудан. *Кауга ут төртү.* | *с. мәгъ. Ул да булмый, чү, янымда бер тавыш. Өззз... итә, нәкъ җилдә шаулый кау камыш.* Н. Исәнбәт.

Кау ут — ут саклау өчен калдырылган учак, калау.

КАУГА *и. диал.* 1. *к.* гауга.

2. *иск.* Афәт-каза килгәнен белдергәндә кага торган зур барабан. *Козгын коркылдаган саен кауга какмыйлар.* Мәкаль. || Шундый барабан куелган урын—гадәттә

авылның кое яки чишмә яны. *Авылы кайда, каугасы шунда.* Мәкаль.

КАУГАЛАНУ *ф. диал.* Кайгырып дулкынлану, хафалану. *Кайсылары „егетне харап иттерер бит", дип, каугаланырга, кайсылары бәреп калдырмагае [айгыр], дип, урамнан балаларын җилтерәтеп алып китәргә тотындылар.* Ф. Хөсни.

КАУГАЛЫ *с. диал.* Гауга, талаш чыгаручан. *Балалы тавык — каугалы халык.* Мәкаль.

КАУДАН *и.* 1. Корыган, саргайган үлән (сабагы). *Җәй айлары үтеп, көз айлары кергән. Агачларның коры чыбыклары, үләннәрнең кипкән кауданнары калган, кыр эшләре беткән.* З. Һади. | *с. мәгъ. Аккан суга кан койма, эчәр суың тапмассың. Кауданжиргә ут куйма, керер куыш тапмассың.* Мәкаль.

2. *диал.* Былтыргы үлән, каудар. *Ишек алдым кауданкаудан, Кауданбашлары ауган.* Җыр.

КАУДАР *и.* 1. Былтыргы куе, биек үләннәр; ягулык итеп кулланыла торган коры үлән. *Учакка кауда р ягу.*

2. *с. мәгъ.* Кабаланучан; ярсып китүчән, кызу канлы. *Сәлим үзе батыр һәм эирәк булып, моның өстенә бик каудар һәм кискен табигатьле дә адәм иде.* Г. Ибраһимов.

КАУДАРЛАНУ *ф.* 1. Каудар холыклыга әверелү.

2. Ашыгу, кабалану; кызып китү. *Фәтхи үзендә һәрвакыт җегәр сизеп, батырларча басып йөри, һичбер эшендә ашыкмый, каударланмый гына алып бара.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Зиннәт, нидер исенә төшкәндәй, каударланып кесәләрен капшый башлады.* Г. Бәширов.

КАУДАРЛЫ *с.* Ашыгычлы, кабалан (күренеш, вакыйга турында). *Каударлы ыгы-зыгы. Нәкъ шул минутта ишектә Тансык күренә.* Ф. Хөсни.

КАУЗЫ *и.* Ат муенына тага торган дүрт почмаклы кыңгырау. *Айлы төннәрдә каузылар шалтыравы, чыклы таңнарда яшь тай кешнәүләре --- ишетелә.* Г. Мөхәммәтшин.

КАУЛАК *и. диал.* 1. Биек булып үскән яшь үлән, курпы. *Каулакта ат ашату.*

2. *куч.* Яңа буын. *Болар [Агыйдел буе башкортлары] баягы тере, җитез, арыслан башкортларның торыннары, каулаклары.* „Шура".

КАУЛАН *и.* 1. Бик биек булып үскән үләннәр. *Кауланга [аулаган] кошың төшмәсен, наданга эшең төшмәсен: кошың табылмый калыр, надан якаңнан алыр.* Мәкаль.

2. Сары чәчәкле биек бер үлән, борынгы медицинада кулланылган.

КАУЛАУ *ф. диал. к.* куу. *Йортлы еланны йортсыз елан каулаган.* Мәкаль. *Карап торам җилнең тау кадәрле Дулкыннарны ярга каулавын.* Ф. Кәрим. *Тоткыннарны хайван көтүе кебек каулап кайтып, янәдән шәһәрдәге таш зинданга бикләделәр.* Ш. Мөхәммәдев. || Кеше малын куып алып китү. *Карт шул секундта ук җавап бирде: — Кукалның малын каулап, йортын яндыруга мин каршы идем.* Г. Ибраһимов.

КАУРЫЙ *и.* Кошлар тиресендәге үсенте, кәүсә сыман каләмнән һәм шуннан тармакланган мамыклы озын төкләрдән тора. *Торна каурыен салган — Аяклары да томшыгы калган.* Мәкаль. *Ак күгәрченнәр кыйгач борылганда, көмеш нурда коенгансыман, бөтен каурыйлары белән ялтырап китәләр.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Каурыйлы, каурыйлардан торган. *Әгәр алар [язгы кошлар], күкләргә ашып, талпына-талпына очалар икән, димәк, каурый канатларында куәт бар.* М. Шабай.

Каурый каләм — очланган һәм карага манып язу өчен кулланыла торган каурый. *Биш-ун минут үтүгә, кәгазь, кара савыты, каурый каләмен сәләмә җиләненең чабуы астына яшереп баракка барганда, шәкертнең башына кызыклы һәм куркынычлы бер уй килде.* К. Тинчурин. **Каурый (каурыйсыман) болыт** — атмосфераның югарыгы катламнарында була һәм тармак-тармак булып, бөдрәләнеп күренә торган ак болыт. *Биек биектә йөзгән каурый болытлар кабыныпфосфористик яктылык сирпеделәр.* А. Расих.

КАУРЫЙ-КАУРЫЙ *с.* Күп каурыйлардан тора торган. *Каз канаты каурый-каурый, Сәлам язарга ярый.* Җыр.

КАУСТИК: каустик сода — зәһәрле натр (натрийлы селте).

КАУЧУК *и.* Кайбер үсемлекләрнең сөт сыман согыннан алына торган эластик сумала, резина һәм резина әйберләр эшләү өчен китә. *Синтетик каучук.* □ *[Татарстанда] зелпе тамырыннан каучук алалар иде. Хәзер зелпе каезлаучылар юктыр инде: каучукны химия бирә.* М. Шабаев. | *с. мәгъ. Ура кычкырып йөреп, Каучук олтаннар туза.* Г. Афзал.

КАУШАНУ *ф.* Тышкы тәэсирдән бигрәк, үз фикерләреннән каушау. *Габделбасыйр каушанып кына „мамык шәллесе Диләфрүз" икән! — дип уйлады.* Ф. Әмирхан.

КАУШАУ *ф.* Көчле кичерештән калтырау, нишләргә белмичә аптырап калу; тотрыксызлану. *Ил чигенә дошман килсә, Каушамас безнең куллар; Мылтык алып алдан чыгар Яшь егетләр, яшь кызлар.* Ә. Ерикәй. *Гадәттә Миңнурый алдында каушап кала торган Сәлим бу юлы тиз генә бирешергә теләмәде.* Г. Әпсәләмов. || Кинәт килеп чыккан катлаулы хәлләрдән югалып калу, фикер чуалу, дулкынлану, тетрәну. *Ул [Гарәфи] минем янга килде дә, шатлыгыннан каушап, кулымны кыса-кыса: „Рәхмәт, Харисов иптәш, рәхмәт", — диде.* А. Шамов. *Гыймади, аз гына да каушамыйча, ашыкмыйча, нәкъ бая туктаган сүзеннән ялгап китте.* Г. Ибраһимов.

КАУШАУЛЫ *с.* Каушаган, әсәрләнгән. *Кемнеңдер каушаулы рәвештә: Вафат... жиназа... — дигән сүзләре ишетелеп калды.* Г. Ибраһимов.

КАУШАНКЫРАУ *ф.* Бераз каушау, каушый төшү. *Безнең юлчылар бу куркынычлы эшелонны янына барып чыккач кына күргәннәр. Башта, берничаклы каушанкырап калган булсалар да, сер бирмәгәннәр.* С. Кудаш.

КАФ: Каф тавы *фольк.* — әкиятләрдә сөйләнә торган зур тау; Кавказ. *Йоклаган ай да бүген төн, Каф тавыннан чыкмаган.* Һ. Такташ.

Каф тавы арты (теге ягы) — бик ерак урын мәгънәсендә. *Малайлар: — Һо! Тондырдымы абзагыз Каф тавының теге ягына! — дип туктаусыз шаулашалар. Гранатаның туктаганын да көтмиләр.* Г. Мөхәммәтшин.

КАФЕ *и.* Зур булмаган ресторан. *Ашханәгә кереп, бер иркенләп утырыргамы, әллә кафеда аягүрә генә капкалап чыгаргамы?* Э. Касыймов.

КАФЕДРА *и.* 1. Докладчылар, ораторлар, лекторлар басып сөйләү өчен махсус ясалган урын, мөнбәр. *Баягы президиум өстәле артыннан торып халыкка баш игән егет кафедра янына килеп басты.* М. Гали.

2. Бер-берсенә якын торган фәннәр яки дисциплиналар буенча белгеч укытучыларның югары уку йорты эчендәге берләшмәсе. *Марксизм-ленинизм кафедрасы. Кафедра житәкчесе.* □ *Мәскәү консерваториясенең вокаль кафедрасы каршында үткәрелгән дәүләт сынавы студия җырчыларының вокаль яктан хәзерлекләре шактый югары булганлыгын күрсәтте.* М. Җәлил.

КАФЕДРАЛЬ: кафедраль собор (чиркәү) — баш вәгазьче урындагы епископ үзе булган зур собор.

Аури елгасы ярлары буйлап йөргәндә кафедраль соборны --- күреп сокланмаска мөмкин түгел. Каз. утл. *Монастырьда чаң суктылар. Бу тавышка --- кафедраль соборның һәм барлык чиркәүләрнең чаңнары кушылды.* Ж. Тәрҗеманов.

КАФЕЛЬ *и.* Стеналарны бизәү өчен кулланыла торган, өсте ялтыравыклы керамик материал. *Кафель шакмагы. Кафель тезү.* | *с. мәгъ. Кояш чыгып, аның нурлары тәрәзә каршындагы кафель мичне ялтырата башлаган.* А. Расих.

КАФЕЛЬЛӘҮ *ф.* Кафельләр белән каплау, каплату. *Кухня электән үк кафельләп эшләнгән иде, хәзер сипләргә генә туры килде.* Г. Әпсәләмов.

КАФЕ'Р *и. к.* кяфер. *Ахуннан кафер туар.* Мәкаль.

КАФЕТЕ'РИЙ *и. к.* кафеханә. *Кафетерийда ашау.*

КАФЕХАНӘ *и.* Кафе яки аның аерым бүлекләре урнашкан бүлмә яки өй. *Парижда --- үзәк урамнарда йорт саен кафеханә.* Г. Гали.

КАФЕШАНТАН *и.* Әчемлекләр һәм ашлар бирелү белән бергә тамашаләр күрсәтү өчен сәхнәсе дә булган ресторан, кафе. *Әгәр без дә ресторан вә кафешантан каһарманнарыннан булсак, истикъбалебез кемнәрдән вә нәрсә генә көтә алыр?* Ф. Әмирхан.

КАФИРӘ, КЯФИРӘ *и. иск.* Кяфер (ислам динендә булмаган) хатын-кыз. *Ул [Зөлхиҗә] дисбесен тартып утырганда, Рәхиләнең кычкырып җырлавын ишеткәч, ялт сикереп торды: — Иблис токымы! Күңелемә вәсвәсә төшермәк булып, такмазаларын акыра, кафирә!* И. Туктар.

КАФИЯ *и. иск. шигъ. к.* рифма. *Вәзенен, кафиясен, басымнарын туры китерә белмәүдә мине, бәлки, гаепләрсез дә.* Һ. Такташ.

КАФИЯДӘШ *и. иск.* Рифмадаш, рифма хасил иткән. *[М. Гафуриның „эшче" поэмасында] бәйләмнәр [строфалар] дүрт юлдан гыйбарәт булып, кафияләре а — в — с — в рәвешендә килә, ягъни беренче һәм өченче юллар төрлечә, икенче һәм дүртенче юллар кафиядәш булып киләләр.* Г. Нигъмәти.

КАФИЯЛӘШҮ *ф. иск. к.* рифмалашу. *Ят нәрсә һәм гажәп түгел, хәтта, — диләр [Бакланов белән Рахманновка], — Килсә җырда кафияләшеп фамилиягез.* Ш. Мөдәррис.

КАФИЯЛӘҮ *ф. иск. к.* рифмалау. *Гыйльман шәкерт --- хатларын гел кафияләп язар иде.* Ш. Хөсәенов.

КАФТАН *и.* Электә русларның озын чабулы өске киеме. *Кучерның башында яшел бүрек, өстендә, русларныкы кебек, киң кафтан.* Г. Әпсәләмов.

КАЧАГАН *с. диал.* Көтүдән яки йорттан качып китүчән (терлек турында). *Качаган сыер.* □ *Качаган кәҗә бүрегә тансык.* Мәкаль.

КАЧАК *и.* 1. Дошман явыннан яки эчке дошманнардан һ. б. качып, илен-йортын ташлап киткән кеше. *Сугыш качаклары.* □ *Болар — качаклар. Шәһәрдәге кибетләрен, зур йортларын калдырып, казак канаты астына сыгынган халык.* Ш. Усманов.

2. Дошман явыннан һ. б. качып йөрү хәле. *Качакта йөрү. Качактан кайту.*

3. *диал. к.* качкын — *Син, качак, нишләп йөрисең? Миннән рөхсәт сорамый, фатиха алмый киттең, — диде Хатыйп мулла.* М. Гафури. || *с. мәгъ.* Качып йөрүчән, качучан. *Сары гөмбәзле озын чиркәү аңа [Хәлимгә] шәһәрдән „йодрык яный" шикелле, „Мин сине, качак малай!" дип әйтәдер кебек иде.* И. Гази.

КАЧАЛКА *и.* Утырып тирбәлер өчен дугасыман табанчага беркетеп ясалган урындык. *Ботактан ерак түгел, үлән өстенә селкенмәле кресло-качалка чыгарып куелган.* Ф. Әмирхан.

КАЧКАЛАК *с.* Качучан, качып китүчән, *[Лаля Мәбрүрәгә:] Качкалак! Әле дә ярый бергә утырмадың. Теге яңа гына килгән сакаллы карт ашап куйган булыр иде үзеңне.* М. Фәйзи.

КАЧКЫ *диал. к.* качкын (1 мәгъ.). *Качкы баласы качкыга булышыр.* Мәкаль.

КАЧКЫН *и.* 1. Хөкемнән, хөкүмәт органнарыннан качып, яшеренеп йөрүче кеше; дезертир. — *Староста, старшина, урәтникләр табаны астында изелеп ятудан кара урман уртасында ирекле качкын булып яшәүне артык табам.* К. Тинчурин. | *с. мәгъ. Бәгъзеләрнең риваяте буенча --- бер Николай дигән качкын поляк шунда килеп урнашкандыр.* К. Насыйри.

2. *с. мәгъ.* Качып китүчән, кача торган. *[Гата белән әнисе] кара син аны, качкын тавык,— диделәр, чуар тавыкны тиргәделәр.* С. Алиш.

КАЧКЫНЛЫК *и.* Качкын булу хәле. *Качкынлыкта йөрү.* □ *Юныс — патша түрәләренә протест йөзеннән --- урманга качып, гомерен качкынлыкта үткәргән кеше.* Каз. утл.

КАЧУ *ф.* 1. Хәвеф-хәтәр көтелгән урыннан, һөҗүмнән яки дошман кулыннан ашыгып һәм күбесенчә яшерен рәвештә китү; читтә яшеренеп яшәү. *Качып бару. Качып китү. Качып котылу.* □ *[Мәйсәрә ялынып:] Булат бәгырем, мине дә, үзеңне дә харап итмә, әйдә качыйк, качыйк.* К. Тинчурин. *Булатны Енисейгә сөрделәр, ул аннан качып кайтты.* Г. Ибраһимов. *— Д фашистлар кулыннан качарга батырчылык иткән кеше, мин беләм, бервакытта да ипташен сатмый.* Г. Әпсәләмов. || Каршы якны, эзәрлекләүчене, каравылчыны һ. б. күздән ычкындырмыйча, яшеренү. *Качып утыру.* □ *Әхмүш агай, бәлки, төн йокламый, Качып кына юкә кискәндер.* Һ. Такташ. *Мин аның [Мәһдинең] качып тәмәке тартканын күреп, ниһаять дәрәҗәдә гаҗәпләнә идем.* М. Гафури. || Качышлы уенында яшеренү, посу. *Әдилдар белән Фәрит кебегрәкләр, йөзеп туйгач, камышлыкка кереп, кача-кача уйнадылар.* Г. Гобәй. || Әйдәүче, оештыручы һ. б. күзенә күренмәскә тырышып, берәр җиргә посу. *Яшел чирәм өстендә кызыл бозау сузылып ята, көтүдән качып калган бер кәҗә читәнгә ышкынып тора.* И. Гази.

2. Очрашмаска, күренмәскә тырышу; читтәрәк йөрү. *Карга үләксәдән, мәзин үлектән качмас.* Мәкаль. || *күч.* Читләшү; баш тарту. *Авырлыктан качу.* □ *Вак буржуаз интеллигентлары --- актив көрәш алып барудан качалар.* Г. Нигъмәти.

3. Мөселман гадәте буенча ирләрдән йөз яшерү, сөйләшмәскә тырышу (хатын-кызлар турында). *Уңмаган килен --- каенатадин качмыйдыр, оятсыздыр.* К. Насыйри.

4. *Юкл. форм.* Нинди дә булса эш яки әйбернең һәрвакыт кул астында булуын, аны теләгән вакытта файдаланырга яки башкарырга мөмкин булуны белдерә. — *Иген өлгерсә, башта байнакын ур, үзеңнеке качмас.* И. Гази.

5. Югалу, җуелу, бетү (яхшы, уңай сыйфатлар турында). *Йөзеңнән оят качу. Бүлмәдән кот качу.* □ *Йокың качкан бугай, шулайдыр шул, Бөркү була кайбер төннәрдә.* Һ. Такташ.

6. Аталану (йорт хайваннары турында).

КАЧУ-ПОСУ *ф.* Каршы якны яки эзәрлекләүчене күзәтә-күзәтә яшеренү, нәрсәгә булса да ышыклана-ышыклана качу, качып бару. *Шунда укыганда, без иптәшләр белән хәлфәләрдән качып-посып кына Шәрык клубына һәм шәһәр театрына спектакльләргә йөри идек.* М. Гали. *Дошман иркенләп котырынсын, ә син качып-посып, кырлар уртасында адашып йөр, имеш.* Ә. Еники.

КАЧЫНУ *ф.* Посарга тырышып, сыенып яшеренү. — *Диләфрүз теге әүвәлге тәрәзәнең пәрдәсе артында качынып калды.* Ф. Әмирхан. *Әнә тагын... ишек ачылып, Берәү... икәү... күләгәләр керә качынып.* Һ. Такташ.

КАЧЫР *и.* Ишәк белән биянең яки айгыр белән ишәкнең кушылгагы. *Касыйм ун качыр иярли дә һәрберсенә зур-зур ике сандык асып урманга китә.* Әкият.

КАЧЫРУ *ф.* 1. *йөкл. к.* качу.

2. Качып китәргә мөмкинлек бирү. *Сәлим, бердан касын кора-кора, качкынга ымлап, Акбүзгә кычкырды:* — *Акбүз, качырасың бит!* Г. Гобәй. || Нинди дә булса мөмкинлекне ычкындыру, файдаланмау. *Кызлар, форсатны качырмыйча, тиз генә идән тактасын капладылар да аның өстенә икәүләп менеп утырдылар.* М. Гали.

3. Яшерү. *Берәү йөгереп килде дә бездән үзен качырып калырга сорады.* Г. Гобәй *Авыл мәктәбендә кизү булып торганда, мин сине, атаңнан качырып, өч көн асраган идем.* М. Гали.

4. Каплату, аталандыру (йорт хайваннары турында).

КАЧЫШ-КАЧЫШ *и. к.* качышлы. *Аннары бер көнне, шул тирәдә качыш-качыш уйнаучы малайлар булса кирәк, ишекнең аскы тупсасын да каерып чыгарганнар.* Ф. Хөсни. *Рәимә - - - ата белән баланың куаклыклар арасында качыш-качыш уйнауларын онытылып карап тора.* М. Хәсәнов.

КАЧЫШЛЫ. *и.* Билгеләнгән бер мәйдан әйләнәсеннән читкә чыкмыйча, бер-береңнән качып уйнала торган уен. *Малайлар клуб янында бик озак качышлы уйнадылар.* Г. Әпсәләмов. *Качышлы уйнарга чакыра әрекмән, кычыткан, куралар.* Каз. утл.

КАШ *и.* 1. Күз уемының өстендә дугаланып торган калку төш һәм шунда үскән куе төкләр. *Кара каш. Кыйгач каш.* □ *Биктаһир картның сакалына, мыегына, кашларына һәм хәтта колак йоннарына хәтле он тузаны сарган.* И. Гази. *Кашларының кыйгачлыгы Карлыгач канатыннан.* С. Сөләйманова.

2. Йөзек-беләзек, брошка һ. б. ш. әйберләргә бизәк итеп беркетелә торган кыйммәтле асыл таш яки металл кисәге. *Кызның чәнчә бармагында кашы йөрәк төсле итеп коелган көмеш йөзек ялтырый иде.* Ф. Хөсни. [*Зөлхәбирә*] *түшенә җем-җем итеп торган зөбәржәт кашлы кечкенә генә брошка кадаган.* Р. Төхфәтуллин.

3. Иярнең алда һәм артта калкып торган ике кырые. [*Хәмдия — Бакыйга:*] *Ал, илче, бу хатны! Ал да, яшь мирзага илтеп, ахак кашлы көмеш иярен сора.* М. Фәйзи.

4. *к.* кашлак. — *Әнә шул кашка чыккач та, Дадашев промыслолары күренер,* — *диде Хәлил.* Ш. Камал. *Иртәнге кояш авыл янындагы каш артыннан яңа гына күтәрелеп чыккан.* С. Җәләл. || *с. мәгъ.* Тау бите сыман калкып торган. *Каш җир түгел, киресенчә, бик аулак уйсу имеш. Арышлар бик сыгылмалы, Газзә бик моңсу имеш.* С. Баттал. *Тиресле җирләрдә, кашрак урыннарда җирләре булган кешеләр аратирә ургалый да башладылар.* М. Гали.

5. *диал.* Калкулык өсте. *Зур-зур таулар башында, Текә ярлар кашында, Тора тезелеп олуг яу.* М. Җәлил. *Байтак юл алгач, сәфәрчеләрнең игътибарын тау кашындагы дәү-дәү комташ кантарлары җәлеп итте.* А. Гыйләҗев.

◇ **Каш астыннан карау** — астыртын ачуланып яки хисләрне һ. б. яшереп карау турында. *Әтисе, кинәт кенә эшеннән туктап, каш астыннан гына Габишка бер тын карап торды.* Ф. Кәрим. **Каш салыну** — ризасызлык яки үпкә белдергәндә кашлар түбәнрәк төшү. *Әтинең ачулы йөзен, салынган кашын күргәч, ул [әни] дә әчтән тына.* Г. Ибраһимов. **Каш сикертү** — кашларны хәрәкәтләндереп ымлау. *Сызылып чыккан кара мыеклы башың белән кызларга бер күз кысып, каш сикертеп куйсаң, хәтәр инде,* — *ди Шәфикъ.* Г. Толымбай. **Каш сикертешле** *иск.* — аулак өйләрдә уйнала торган гыйшык уены. *Аннан аулак өйдәге барлык яшьләр, кызлар куырылган борчак ашыйлар. Уеннар китә... Каш сикертешле уйныйлар.* С. Рафиков. **Каш тарту** — кашларны махсус карандаш белән буяп каралту. *Шәһәр тумасы бит минем Миһриҗамал, үзенә күрә түгел, чәчләрен бөдрәләтеп, кашлар тартып, чәмчәле читекләр киеп кайткан.* М. Гали. **Каш төзәтәм (ясыйм) дип күз чыгару, күз чыгарып каш ясау** — кечкенә бер файдалы эш эшлим дип, зур зыян китереп чыгару. *Каш төзәтәм дип күз чыгаруың, планны өзүең бар.* Ш. Бикчурин. **Каш җимерү (сындыру)** — ризасызлыкны, җәберсенүне белдергәндә кашларның табигый торышын бозу. [*Сафа*] *кашларын җимереп, усал итеп, түбән карап йөри башлады.* А. Шамов. *Хәлим аягүрә басты да борынына төшеп торган кепкасын ачу белән күтәреп җибәрде, кара кашларын сындырды.* И. Гази. **Каш җыеру (җыерылу)** — ризасызлыкны яки аптырауны, фикер көчәнешен белдергәндә ике каш арасын җыеру (ике каш арасы җыерылу). *Әбинең кәгазен алып укыгач, Мансуров кашларын җыерып, башын чайкап куйды.* Г. Бәширов. *Шәмитның балкып, нурланып торган күзләре сүрелеп китте. Кашлары җыерылды.* А. Расих.

КАШАВАЙ: кашавай чана — утырып бару өчен махсус җайланган, артлы (күшле) чана. *Кашавайга утырып бару.* □ *Туйга барсаң җик кашавай: Чана печән ашамай.* Мәкаль.

КАШАГА *и.* 1. Тәрәзә яки ишек өсте турысына эчке яки тышкы якта горизонталь кадакланган такта. *Почмакның бердәнбер тәрәзәсенең кашагасына элеңгән кызыл башлы сөлгедән - - - башка бер төрле дә җиһаз күренмәде.* К. Тинчурин.

2. Эчке стенаның югары өлешенә, ишек, тәрәзә башларына яки матчага — шнурларга, кадаклар рәтенә эленә торган бизәкле, озын тукыма. *Тәрәзә башларына эре парчалы, ситсалардан тегелгән кашагалар элеңгән.* Г. Галиев.

3. Мич авызы өстендәге киштә сыман чыгынты яки уенты; кучкар. — *Ай, әнә шул мич кашагасындагы тозның бөтенесен салып корырга* [*мылтыкны*]*!* Г. Гобәй.

4. *диал. күч.* Бүрекнең маңгай турысына тегелгән һәм гадәттә төшерелмәслек итеп беркетелә торган козырегы. *Локман кашагасы белән артка карап торган бүреген әйләндереп киде.* Чаян.

КАШАГАЛАУ *ф.* Кашагалы итү, кашага кую. *Тәрәзә кашагалау.* □ *Өскә кашагалап корган чыбылдык күгелҗем ак төстә, күтәренке җәйге ак болытлар төсле тора.* Н. Исәнбәт.

КАШАК: урман кашагы *и* — Урман кырые. *Урман кашагына якынлашу. Урман кашагы буйлап салынган юл.*

КАШАЛОТ *и.* Тешле китлар семьялыгыннан зур башлы имезүче хайван.

КАШАУ *и.* Атның тәнен кырып тазарту өчен махсус кыргыч, ат кыргычы. *Атның яме ашавы белән дә кашавы белән.* Мәкаль.

КАШАЯК *и. Сөйл.* 1. Вак-төяк савыт-саба кую өчен махсус шүрлек. *Стенага кашаяк беркетү.*

2. *к.* кашык-аяк.

Кашаяк мунчаласы — савыт-саба юа торган мунчала төргәге. *Чөйләргә акка кызыл белән чигелгән берничә озын сөлге, кул һәм аш-су тастымаллары, кашаяк мунчалалары эленгән.* И. Туктар.

КАШБАУ, КАШМАУ *и. этн.* Алгы ягы сәйләп, энҗе һәм тәңкәләр, асыл ташлар белән бизәлгән тасма яки такыя сыман хатын-кыз баш киеме. *Зәңгәр күлдә яшел төнбоек, Чәчкәсеннән кашбау ишәрмен.* М. Җәлил. *Карчык --- вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын --- олы кызы Сылубикәгә билгеләп тора.* Ә. Еники.

КАШЕВАР *и. сөйл.* Хәрби бүлектә яки эшчеләр артелендә аш пешерүче. *Кашеварлар аны [яңа кухняны], яшь киленне каршылаган шикелле, кадерләп, сыйпап, сөеп каршы алдылар.* Ш. Усманов. *Мин Троицк байларыннан бер байның заимкасында эшчеләргә аш-су хәзерләп, кашевар булып хезмәт иткән идем.* М. Гафури.

КАШЕМИР *и.* Йомшак, юка йон тукыма. || *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән яки кисеп алынган. *Кашемир күлмәк. Кашемир яулык.* □ *Кызлар бар да киенешкәннәр, бизәнгәннәр. Чуар кашемир шәлләр, зур яулыклар бөркәнеп, алъяпкычлар бәйләгәннәр.* М. Фәйзи.

КАШКА *и.* 1. Хайваннарның маңгаенда була торган ак тап, ак йон үскән төш. *Менә ул [колын] миңа алды белән әйләнә. Ни күзем күрсен, маңгаенда кечкенә генә агы — кашкасы бар.* Ш. Әхмәдиев. *Айгырның маңгаеннан борын очына кадәр ак кашка сузылган.* Г. Лотфи.

2. *с. мәгъ.* Маңгаенда ак тап, ак йон үскән төше булган. *Кашка бозау. Кашка бәрән.* □ *Алда Теләче чиркәвенең алтын гөмбәзе һәм базар мәйданындагы калай түбәле өйләр, кибетләр ялтырап күренде, кашка айгыр йөрәк кага-кага әлдертә башлады.* Ф. Хөсни.

3. Кашкалы ат. *Җирән кашка, яшь булса да, көчле икән: шулчаклы печән белән биш кешене йөгертә.* Г. Ибраһимов. *Югары күтәрә кашка Бантиклы башын.* Ф. Кәрим.

КАШКАЛАК *и.* Су тавыгысыманнар семьялыгыннан урта зурлыктагы ак маңгайлы бер кош. *Хан углына кашкалак, би углына бизгәлдәк.* Мәкаль.

КАШКАЛЫ *с.* Маңгаенда кашкасы булган. *Сыртлан Сәли ак кашкалы туры атта юл буйлап җәй гына юыртып бара.* Р. Төхфәтуллин.

КАШКАРА *и.* Кашны каралту өчен махсус буяу. *[Сәхилә:] Дй, үземдә соң кызларның асылы. Кашкара тарткан кирәкме, тешкара тарткан кирәкме?* Н. Исәнбәт. *Кашкаралары кирәкми, Үз кашларым да кара; Кеше ярлары кирәкми, Үз ярларым да кала.* Җыр.

КАШКАРЫЙ *и.* Кыргый астра. *Кашкарый чәчәге. Кашкарый гөле.* □ *Зәйтүнә кулы тигәнгә хуш исле ул йолдыз чәчәкләре, тырнаклы гөлләр, кашкарыйлар.* Г. Мөхәммәтшин.

КАШКИ *иск. терк.* Үкенеп, бер эш, хәлнең булуын күпсенеп яки булуын теләп әйтелгән җөмләләр белән килә; әгәр, гәрчә. *Кашки шул бер елны гына күрмәгән булсамчы! Шул бер елда картаюым, шул бер елда бетүем!* М. Гали. *Бу егет — гүзәллектә Йосыф пәйгамбәр, Булсачы, кашки, бер җаваплы хезмәткәр.* Ә. Исхак.

КАШКЫР *и. диал.* Дала бүресе; гомумән бүре. *Качаган мал кашкырга җим.* Мәкаль.

КАШ-КҮЗ *җый. и.* Каш һәм күз. *Кашың-күзең кара, калганын үзең кара* [Табигать биргән уңай сыйфаттан файдалана белү турында]. Мәкаль.

КАШЛАК *с.* Калкып чыгып торган, калку (рельеф турында). *Әйбәт тә соң алмагачка Җирнең бераз кашлагы.* С. Хәким. *Тау башындагы кашлак урыннарда кар инде әреп беткән.* Ф. Хөсни. | *и. мәгъ.* *[Газинур] фермалар артындагы кашлакта казыла торган землянкаларга таба юнәлде.* Г. Әпсәләмов.

КАШЛАН *и.* Калку кыр, калку җирдәге басу. *Әнкәй безне сезнең кашланга чәчкән борчакларыгызны ашарга алып бара иде.* Ак юл.

КАШЛЫК *и.* Зур булмаган калкулык; тау бите. *Йөгерешеп качты малайлар якындагы кашлык артына.* М. Сөндекле.

КАШМА *и. диал.* Киез келәм, бизәкле киез җәймә. *Идәнгә кашма җәю.*

КАШНЕ *и.* Киң йомшак шарф. *Мусаның өстендә кул белән бәйләнгән свитер, аның өстеннән соры вискоз кашне уралган.* Ш. Маннур.

КАШТАН *и.* 1. Урта пояснең җылырак якларында үсеп, аксыл коңгырт төстәге чикләвек бирә торган агач. *Ялкын, дәрт җыеп, югарырак ыргылганда, куе яфраклы каштаннарны, караңгы тәрәзәле йортларны яктыртып ала.* Г. Әпсәләмов. *Күргәнем юк иде каштаннарның ап-ак булып чәчәк атканын.* З. Мансур.

2. Шул агачның саргылт-көрән төсле, юка кабыклы чикләвекләре. *Каштан кыздыру (куыру).*

3. *с. мәгъ.* Каштан җимеше (каштан чикләвеге) төсендәге. *Каштан чәч.*

КАШУ *ф.* 1. Гадәттә тырнаклар белән тәнне каты итеп ышку, тырнау. *Галләм абзый, Нургалинең сүзләренә кушыласы килмәгән бер чырай белән ияген күтәреп, сакал астын кашый.* Ә. Еники. *Малай, аягын аягы белән кашып куйды.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Камчылау, таяклау, кыйнау. — *Тик менә шунысы, — диде Миңнулла, — алпут җиренә ташлана-нитә калсак, бишенче елдагы кебек арканы кашымаслармы?* И. Гази.

КАШУЧ, КАШАВЫЧ *и. диал. к.* кашау.

КАШУЧЛАУ *ф.* Атны кашау белән чистарту, кыргычлау. *[Кәрим:] Галәви! Син нишлисең анда?! Кашучлап бетергәч, тарантаска җигеп куй.* Г. Камал.

КАШЫК *и.* 1. Бер кабым аш сыешлы, озынча саплы сай савыт. *Өстәлгә ике тәлинкә, юка гына итеп тураланган ипи телемнәре һәм ике кашык куелган.* А. Гыйләҗев.

2. *күч.* Гаиләдә үзенә азык өлеше таләп итүче аерым шәхес, жан. *Марат килгәч, [Илдар белән Сания-нең] әниләре, бер кашык артты дигән булып, чуенны тутырып пешерде.* Г. Гобәй. *Без ул вакытны барыбыз ун кашык идек.* Г. Толымбай.

◇ **Кашык күтәрү** — 1) азыклану, тукланып тору (гаиләдәге җан башына карата). *Авылда абыйның көймәсе комга терәлгән. Бер иманага алты кашык күтәрәләр.* К. Тинчурин; 2) мөстәкыйль рәвештә ашый белә башлау (бәбиләр, нарасый балалар турында). — *Зурысы унөчкә чыкты. Болары яңа гына кашык күтәрә башладылар, — диде әни.* Х. Садри.

КАШЫК-АЯК, КАШЫГАЯК *җый. и.* Төрле савыт-саба (кашык, тарелка, чүмеч һ. б.) — *дйдә әле, кызый, миңа кашык-аяк юыш әле.* Ф. Әмирхан. *Киң күлгә-ле юан өрәңге төбенә бик олы җеп палас җәйгәннәр, аның өстенә табак-савыт, кашык-аяк, ипи-тоз таратып табын әзерләнгән.* Ш. Маннур.

◇ **Кашык-аяк шалтырау** — гаиләдә вак-төяк ызгыш-талашлар булу. *Кашык-аяк шалтыраган саен, хатын аермыйлар.* Мәкаль. *Тормыш булгач, кашык-аяк шалтырамый тормый.* Мәкаль.

КАШЫКЛАП *рәв.* 1. Кашык сыемы белән. *Кашыклап җыйганны чүмечләп түгәсе килми.* Мәкаль. *Кая инде ул вакытта онны потлап үлчәү. Кадаклап та гәрәнкәләп яки кашыклап үлчи торган чак иде.* М. Хәсәнов.

2. Кашыкны тутырып, кашык белән. *Кофены кашыклап кына [авыруның] авызына салырга кирәк.* Ш. Маннур.

3. *күч.* Аз-азлап, вак өлешләр белән. *Мәхәббәтеңне кашыклап өләшү.* □ — *Ташы мәгърифәтне авылга,*

Хәнәфи абзый, кашыклап булса да ташы! Г. Бәширов.

КАШЫКЛЫК *и.* 1. Кашык ясауга китә торган агач. *Кара урманнарның уртасында Кучаланып үскән кашыклык.* Җыр.

2. Кашыклар, чүмечләр һәм тәлинкәләр куела торган махсус киштә. *Стенаның нәкъ шул сандык торган тәнгәлендә кашыклык ясалган.* М. Гафури.

КАШЫНУ *ф.* Үз-үзеңне еш-еш кашып тору; тәннең кычулы төше белән берәр нәрсәгә ышкыну. *Сыер өй почмагына килеп озак кына кашынып торды.* А. Гыйләҗев.

КАЮ I *а. иск. к.* кайсы. *Бай әйтте: „Җәмәгать,— диде,— һәр каюгыз беләсез, дошманнарым нахак бәлагә грифтар кылдылар".* Г. Ибраһимов. *Бу шәһәрдәге барлык учреждениеләрдә аппаратны тазартү үткәрелеп вә һәр каюсында моның өчен махсус комиссияләр оештырылып, чит элементларны куып чыгарырлар иде.* Ә. Исхак.

КАЮ II *ф.* Материя яки күннең читен чигеп яки тегеп бизәкләр төшерү. *Атлас белән кайый ул якасын, Ука белән тота җиң очын.* М. Җәлил. *Аклы күлмәк матур була Якаларын каегач.* Җыр.

КАЮК *хәб. гади. с.* Бетте, тәмам, һәлак. — *Шулай, ике-өч көн эчендә боларга каюк, кызым, совет власте килә, үзебезнең власть килә, — диде Бикмуш бабай.* Г. Гобәй.

КАЮЛЫ *с.* Каелган, каеп чигелгән. *Сөләйман итәкләре каюлы ак күлмәк киеп, өстеннән зәңгәр зинар баглаган.* Ф. Әмирхан.

КАЮ'ТА *и.* Зур көймәләрдә, корабларда команда кешеләре яки пассажирлар өчен бүлмә. *Безне пароходның икенче катындагы бер каютага керттеләр.* Г. Мөхәммәтшин.

КАЮТ-КОМПА'НИЯ *и.* Көймәләрдә һәм корабларда ашау-эчү, ял итү һ. б. өчен уртак зур бүлмә. *Каютт-компаниягә җыелу.* □ *Кичке ашка теләр-теләмәс кенә чыктым. Кают-компаниядә сәер, бастырынкы тынлык иде.* И. Низамов.

КАЯ *сор. а.* 1. Кайсы җиргә, кайсы якка. *Иптәш, әйтегез әле зинһар, бу поезд кая бара?* А. Шамов. *Бер көнне диде Тавык: „Туганкаем, кая барып кайтасың син һәр көн саен?"* М. Гафури. | *рәв. мәгъ. Аннары, бездән ерак түгел, юл аермасында туктап, кая барырга белми торган берәр атлы юлаучы, кул изәп безне чакырып алып, кая да булса берәр авылга китәргә юл сорый.* М. Гали.

2. *мөн. сүз.* Баш җөмләдәге анда, шунда сүзләре белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен урын җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Кая карама — ак, соры, яшел, чуар, чәчәкле-гөлле, ямаулы-ямаусыз чаршаулар эленгән.* И. Туктар.

3. *кис. мәгъ. сөйл.* Әңгәмәдәшнең сүзләре белән килешмәгәндә яки көтелгән, фараз ителгән халәтнең чынбарлыктагыннан аермасы зур булуын риторик сорау белән белдергәндә кулланыла. *Карап тик утыра, песи, тавышка илтифат итми: Кая курку дигән нәрсә? Колак, койрык та селкетми.* М. Гафури. *Кыйнашырга кая, Арыдым әле.* Х. Туфан. *Кая байларга каршы төрып сүз кушу, хәтта күз караулларыннан курка идек.* Ш. Мөхәммәдев. | **инде, әле** кисәкчәләре белән. *Безнең шикелле кара шкмәк ашап үскән кешегә кая инде аксөяк булу.* М. Гали. *Кая әле миңа аларга үрелергә!* Г. Бәширов. || Үткән заман сыйфат фигыльнең юклык формасы янында килеп, риторик раслау әйләнмәсе төзи. [*Рәхимҗан:*] *Белмәгән кая, беләм, бик беләм, бер бөртеге дә әрәм булмас.* Р. Ишморат.

4. *сор. а. сөйл. к.* кайда. *Кая соң сез, Гейне һәм Марксны Тыңлап үскән мәгърур егетләр?* М. Җәлил.

5. *хәб. функ.* Риторик җөмләләрдә: „кая китте, кайда, нишләп юк" мәгънәсен белдерә. *Айсылу! Кая синең ялкынлы сүзең, кая җитезлегең!* Г. Бәширов. || „Биредә бармы, юк бит" мәгънәсендә. *Монда намус кая, вөҗдан кая, тәрбия кая?* Г. Ибраһимов.

6. *ы. функ.* Тыңлаучының игътибарын җәлеп итү, аны нинди дә булса берәр эшкә тарту өчен кулланыла. — *Кая, кызым, тартмадагы күзлегемне китер әле.* А. Әхмәт. *„Кая әле, тотчы, син, артельщик", — диде Исак.* Ш. Камал.

◇ **Кая бара (барып чыга), кая китә** — эш бер эзлеклелек белән шулай барса, бик начар яки кабул ителмәслек нәтиҗәгә китерәчәген кисәтү өчен кулланыла. *Әшендә чатаклык чыкты дип, кешене юк итә башласалар, кая китә ди ул!* М. Хәсәнов. **Кая басканны (басарга) белмәү** — шатлыктан яки башка сәбәптән бик җанлану, тынычлана алмау, бик җиңел йөрү. *Җәмалиның башы күккә тиде. Куанычыннан кая басарга белмәде.* Г. Ибраһимов. *Көне буе кая басканын белми йөрде Гәрәй.* А. Гыйләҗев. **Кая кую** — нишләтү, нинди хисапка кертү (кем яки нәрсә турында булса да искәртеп әйтелә). — *Син, Нәсимә җиңги, — диде Кара Хәсән, — алай итеп бер кешене генә мактап маташма. Һидият белән Җаббарны кая куясың?* Ш. Камал. — *Алдау була бит ул... Гөнаһсын кая куярмын икән соң мин аның? — диде апам.* А. Шамов. **Кая куырга белмәү** — нишләргә, нишләтергә белмәү. *Бөтен өметләре юкка чыккан һәм көнләшүдән үз-үзен кая куырга белми йөргән Сәлим, тыштан бер дә исе китмәгән кешегә салынып, түйга килде.* Г. Әпсәләмов. *Хәлим, көчен кая куярга белмичә, сабанны этеп бара башлады.* Г. Гобәй. **Кая ул** — 1) „ерак тора, бөтенләй киресенчә: якын да килми" мәгънәсендә. *Күрәсең, баю турында уйлау кая ул, эшләп алган акча тамак туйдырырга да чак-чак җитә.* Г. Нигъмәти. *Борһан элеккеге Борһан түгел инде. Кая ул! Басылган.* М. Хәсәнов; 2) „ихтималы да юк" мәгънәсендә. — *Кызларның күп чагы, мин әйтәм, үзеңә ошаганны сайла да өйлән... Юк, кая ул, кулын гына селки. „Миңа бүтән кирәкми", имеш.* Г. Бәширов.

КАЯГЫ *с.* Каян килгән; кайсы якныкы. *Кичәге яшь егет [Рөстәмгә] ашарга китерә, [аның] каягы икәнен сораша.* С. Җәләл.

КАЯЗ *и.* Карп сыман балык төре; *русчасы:* **усач.**

КАЯН *сор. а.* 1. *к.* кайдан.

2. Нишләп, ни сәбәпле, нилектән, ни өчен (шелтәле сорау аһәңе белән әйтелә). *Нәфисә: — Әти, кара әле, бу ни эшең бу? — диде. — Әйтче зинһар, сиңа нәрсә җитми? Бу хурлыкны каян уйлап чыгардың?* Г. Бәширов.

◇ **Каян килү** — ничек барлыкка килү (гаҗәпләнү яки һичсүзсез инкяр итү аһәңе белән әйтелә). [*Сания Гөлзадәгә:*] *Син ничек ачык һәм кыю итеп сөйлисең хәзер. Каян килде сиңа бу кадәр кыюлык?!* Р. Ишморат. *Очрашулар каян килер иде, Аерылулар әгәр булмаса.* З. Нури. **Каян килеп, кая китмәгән** — кызганырлык түгел, күп нәрсә югалтылмый мәгънәсендә (сарыф булган кыйммәт, мал, акча һ. б., шулай ук вакыт турында). *Хатын әйтә: — Булмаса, карт, хәзрәттән яңа бөти яздырып кайт, унбиш тиен каян килеп кая китмәгән.* С. Җәләл. — *Бер киклек [киек кош] каян килеп кая китмәгән. Окоптагылар өчен бирәм, — диде карт.* Ә. Айдар.

КАҢ *аваз изәр.* Казлар кычкырган тавышны белдерә. *Карга мең карылдаса да, яз булмас, каз бер каң итсә дә, яз булыр.* Мәкаль. *Дә ничек ак каз, каңкаң килеп, Канатларын җилпеп кагына.* М. Гафури.

КАҢГЫ *и. бор.* 1. Күчмә тормышта көнкүреш кирәк-ярагы төялеп йөртелә торган бик зур арба.

Тотыш углан [кеше исеме] яткан ялгыз тирмәне, сүтеп тормыйча, киң арбага — каңгыга урнаштырдылар. Н. Фәттах.

2. Походта запас кораллар төялгән арба, күчмә арсенал. *Кыз бала — каңгыда яткан ук.* Мәкаль.

КАҢГЫЙ *и. иск.* Әкияттәге тау иле, ерак һәм билгесез җир мәгънәсендә. *Бүз бала: каңгыйдан кыз ала.* Мәкаль.

КАҢГЫЛ: каңгыл сөякле *диал.* — яңак калкымы зур булган, яңак, бит сөяге чыгып торган. *Каңгыл сөякле бит.*

КАҢГЫЛДАТУ *ф.* Каз кычкырганга охшашлы өзек һәм яңгыравыклы аваз чыгару. *Зиннәт гармонен каңгылдатып бер тартып алды.* Г. Бәширов.

КАҢГЫЛДАУ *ф.* Каң-каң итеп кычкыру (казлар турында). *Карга карылдап кар теләр, каз каңгылдап яз теләр.* Мәкаль.

КАҢГЫРУ, КАҢГЫРАУ *ф.* 1. Миңгерәү, тинтерәү, зиһенсезләнү. *Варис --- киртәгә таянып, шактый вакыт каңгырап басып торды.* М. Хәсәнов. || Урын эзләп аптырау; эзләгәнеңне таба алмыйча йөрү. *Кайчан карама, урам буйлап кемнәр терлеге каңгырып йөри дисәң, шуларныкы булып чыга.* А. Шамов.

2. Күнекмәгән, гадәтләнмәгән шартларда, чит илдә яшәү. *Ике ел буе горбәттә, җәфалар, куркынычлар арасында каңгырып йөргән Төхфәт өчен бәләкәй өйнең --- почмагына килеп сыену күңеленә рәхәтлек бирә.* Ш. Камал.

КАҢКАЮ *ф.* Муенны сузган килеш катып калу. [*Бәбкәле каз бәбкәсезенә:*] *Нишләп ялгыз башыңны каңкайтып, минем балаларым янында йөрисең? — ди.* Г. Галиев.

КАҢСА *и. диал.* Махсус формадагы сөяк төрепкә, челем. *Каңсасын бер дә авызыннан төшерми торган Корман агай бик гади кеше.* Ш. Маннур.

КАһАРМАН *и.* 1. Батыр көрәшче, герой. *Бездән уңбиш чакрымда Мәргәнташ дигән биек бер тау бар. Башкортлар, Салават каһарманның якын дусларыннан Мәргән шунда күмелгән, дип сөйлиләр.* Г. Ибраһимов. — *Минем фаразымда гүя ул бер каһарман, тиңдәшсез баһадир — хикәяләрдә сөйләнгән падишаның кече улы.* Ш. Камал. || Берәр эштә аеруча үзен күрсәткән, төп урында торган кеше. *Килүчеләргә, оста гына итеп, Херсонскоега һөҗүмне сөйли башладылар. Бу эшнең каһарманнары — кавалеристлар.* Ш. Усманов. | *с. мәгъ. Татар халкы үзенең Гайфуллин Закир кебек атаклы каһарман уллары белән мактана.* Ш. Мөдәррис.

2. Әдәби әсәрдә сурәтләнгән һәм укучының игътибар үзәгенә куелган образ; герой. *Комедиянең баш каһарманы — Хәмзә бай.* Ф. Әмирхан.

КАһАРМАНЛЫК *:* 1. Каһарман булу; батырлык. *Фатыйма --- „каһарман“ исемен алмыш иде. Каһарманлыгы өстенә гүзәллеге дә тәмам килгән иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Каһарманнарча эшләнгән эш. *Зурларның, агаларының каһарманлыклары аның [Шәяхмәтнең] күз алдында үттеләр.* Г. Ибраһимов. *Бабичның сатира коралын күтәреп кискен көрәшкә чыгуын иҗат каһарманлыгы димичә мөмкин түгел.* Х. Госман.

КАһАРМАННА'РЧА *рәв.* Каһарманнарга хас булганча, каһарманнарга охшаш. *Савелий бабай җитәкчелегендә штабта дежур торган унлап партизан, японнарга каршы соңгы һөҗүмгә ташланып, каһарманнарча һәлак булдылар.* И. Туктар.

КАһВӘ *и. иск. к.* кофе. *Ике нәрсә харап итте җиһанны: Йәмәннең каһвәсе, Румның доханы [тәмәкесе].* Мәкаль.

КАһВӘХАНӘ *и. иск.* Кофе эчә торган урын, кафе. *Каһвәханә хезмәтчесе яһүд Енгел Шубинга чәй китерде.* З. Бигиев.

КАһВӘЧЕ *и. иск.* Кахвәханә тотучы; каһвәханә хезмәткәре. *Каһвәчеләр каһвәханәсене ачып, сату итә башладыгы кеби, урамнарда, базарларда халык та ары-бире йөреп кайный башлаган иде.* Ш. Мөхәммәдев.

КАһКАһӘ *и.* Тыйнаксыз хахылдау, мәсхәрәле көлү. [*Камилә*] *булган җирдә уен, көлке, каһкаһә күтәрелә.* Г. Ибраһимов. *Дәрвиш йөзекне алганда, үткен бер сызгыру тавышы белән нечкә генә каһкаһәләп көлү тавышлары ишетелә. Ул каһкаһәләр бушка булмаган икән.* Ш. Камал. || Мыскыл, сарказм. *Синең тавышыңда: — Син бичара татар кызы, Офелияләр үстерә аласыңмыни? — дигән каһкаһә бар иде.* Г. Кутуй.

КАһКАһӘЛЕ *с.* Ачу катыш мыскыллы, саркастик. *Җырның сүзләрендә тормыш белән саубуллашу, сугышка китүчеләрнең тавышларында каһкаһәле ачу бар иде.* Л. Гыйльми.

КАһКАһӘЛӘҮ: каһкаһәләп көлү — кычкырып, мыскыллап көлү, каһкаһәле көлү. *Әле берүнең бугазына үзенең тырнагын батырып, әле икенченең гомерен өзеп, каһкаһәләп көлә-көлә, әҗәл котырып йөри икән.* Ф. Хөсни.

КАһӘР *и.* 1. Каргышлы җәза. *Алланың бер каһәредер дип, Нурый түзәргә булды.* Г. Ибраһимов. || Каты мөнәсәбәт; рәнҗетүле мөгамәлә, шәфкатьсезлек. *Сугыш, сугыш! Нәрсәне генә үз каһәреңә буйсындырмадың син.* Г. Гобәй.

2. Каты ачу. *Кайгы күздән, каһәр йөздән беленә.* Мәкаль.

3. *тир.* Каһәрләүгә, каргышка лаеклы нәрсә. — *Бетми торган бу каһәрләр нинди халык?* М. Гафури. || Вак-төяк каршылыклар, кыенлыкларга, шулай ук дошман итеп саналган кешеләргә карата ачусыз гына әйтелә торган каргау сүзе. *Галәү бабай сукранасукрана тәрәзгә килде. — Әле генә йокыга китеп бара идем, каһәр. Шырпысы кайда соң әле?* Г. Гобәй. | Соклану аһәңе белән әйтелә. *Хәйләкәр дә соң минем апам! Шуны гына көткән икән, каһәр. Дөтүем булды, авызы ерылып китте.* А. Шамов. *Былтыр әнә алма сатучының кызы күңелне әллә нишләтеп китте бит. Төшкә кереп йөдәтеп бетерде, каһәр.* Ф. Хөсни.

◇ **Каһәр салу** — интектерү, газаплау, җәфалау. *Теләсә кемнең сарыкларын урлап суеп, авылга каһәрләрен салдылар алар [дезертирлар].* Г. Лотфи. **Каһәр суру (төшү)** — берәрсенең ачуы, рәнҗеш-каргышы нәтиҗәсендә бәла-казага дучар булу, җәзасын күрү дип уйлау. *Шул төнне яшеннән ут чыгып, алпавыттан калган әйбәт нарат өйләр, амбарлар яныпбетәләр. Карт-карчыклар исә: — Яшен сукмады, алланың каһәре сукты! — дип юрап куйдылар.* Г. Ибраһимов. *Гайнүк әби: — Алланың каһәре төште, соңгы кәҗәмне алырга килделәр, — дип, яшьләрен җиң очына сөртә-сөртә, сөйләнеп китте.* Һ. Такташ. **Каһәр суккан, суккыры (каһәр төшкән, төшкере)** — бик ачынып каргау сүзе. *Ул каһәр суккан нәрсәләр [кәҗә бәтиләре] кое янындагы атлар әчерә торган улак белән генә дә чикләнеп калмадылар, ә кое бурасы өстенә сикереп менеп, шунда маңгайга-маңгай сөзешә башладылар.* Г. Әпсәләмов. *Каһәр төшкән япончар, кәрлә булсалар да, бик каты йөгерәләр.* А. Шамов.

КАһӘРЛЕ *с.* 1. Каргаулы, ачулы. *Яңгырый авыр үткәннең Зарлы, каһәрле җыры.* Ш. Маннур.

2. Бик җәфалы, интектергеч, борчулы. *Каһәрле язмыш.* □ — *Сәгать саен яңа куркыныч, яңа авырлык. Я, нинди каһәрле дөнья бу?* К. Тинчурин.

— *Тирә-ягымны каһәрле сораулар чолгап алганнар да, миңа һөҗүм итәләр.* Ә. Фәйзи. || Каты, шәфкатьсез. *Каһәрле дошман.* □ *Елаган, ялварган саен аның эткәсе каеш чыбыркыны катырак селти, Хәлимәнең әләккән бер җиренә каһәрлерәк суга иде.* Ш. Камал.

КАҺӘРЛЕК *и.* Шәфкатьсезлек, рәхимсезлек; җәзалаучанлык, үч. *Каһәрлегең килү. Күңелдә каһәрлек саклау.* □ *Мөстәбидләр [кол биләүчеләр] --- каһәрлек белән даннар чыгарган.* К. Тинчурин.

КАҺӘРЛӘНҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* каһәрләү. *Каһәрләнгән дөнья. Каһәрләнгән, изелгән халык.*

2. Бик ачынып әйтү, каргау, сүгенү. *Касимханов каһәрләнде: Ничек телең бара шундый сүзне әйтергә!* Г. Минский.

КАҺӘРЛӘҮ *ф.* 1. Каргау, янау; сүгү, тиргәү. *Бирем әкә үткән заманнарның хәлләрен сөйләде. Әбелхәер ханны каһәрләде.* Г. Ибраһимов. *Каһәрлисең дөньясын син: Асты-өскә күтәрелсен! Әй син үзең ни кылдың соң Аны матур итәр өчен?* З. Мансур.

2. Бик каты тоту; шәфкатьсез җәзалау. *Залим Россия хөкүмәте, кан эчүче бюрократия, юан корсаклы буржуазия бичара җирсез-сусыз, ач-ялангач авыл халкын талап, казаклардан суктырып, аттырып каһәрләгән.* Ш. Мөхәммәдев.

КВАДРАНТ *и.* 1. *мат.* Түгәрәкнең дүрттән бер өлеше, сектор.

2. *астр.* Күктәге яктырткычларның биеклеген почмак ярдәмендә үлчи торган борынгы прибор.

3. *хәрби.* Артиллерия орудиеләрен вертикаль юнәлеш буенча төзәгәндә почмаклар үлчәү приборы.

КВАДРАТ *и.* 1. Барлык яклары тигез булган турыпочмаклык. [*Агачка*] *хәрефтән соң куела торган квадратлар агачның сортын күрсәтә.* Г. Әпсәләмов. || Шуңа охшаш нәрсә турында. *Кукуруз начар, чүпле, сирәк, җитмәсә, шактый урыннарда квадратлар дөрес чыкмаганнар.* С. Рафиков.

2. *мат.* Нинди дә булса санны үз-үзенә тапкырлаганнан килеп чыккан тапкырчыгыш. *Практик исәпләүләр өчен саннарның квадратлары бирелгән махсус таблицалар төзелә.* Алгебра.

Квадрат метр — мәйдан үлчәү берәмлеге (иңе һәм буе берәр метр булган мәйдан). *Ун меңнәрчә квадрат метрга газон, меңнәрчә квадрат метрга чәчәклек ясалган.* Азат хатын. **Квадрат җәя** — [ ] формасындагы җәя. **Квадратка күтәрү** — 1) санны үз-үзенә тапкырлау. *Төрле квадратларның мәйданнарын исәпләп чыгарганда, саннарны квадратка күтәрергә туры килә.* Геом.; 2) *күч.* Нәрсәне дә булса арттыру. *Ник күтәрдек квадратка, кубка Җан ачуын, күңел тарлыгын.* М. Хөсәен.

КВАДРАТЛАП-ОЯЛАП: квадратлап-оялап утырту (чәчү, үстерү) — рәт араларын эшкәртү җиңел булсын өчен, орлыкларны бер-берсеннән аркылыга-буйга билгеле бер ара калдырып утырту яки чәчү. [*Сәфәргали:*] — *Мин чөгендерне квадратлап-оялап үстерүнең нәтиҗәсен күзәттем. Бу ысул аны ике юнәлештә — аркылыга да, буйга да эшкәртергә мөмкинлек бирә икән.* Г. Галиев.

КВАДРАТЛАУ *ф.* Квадрат формасын бирү, квадратларга бүлү.

КВАДРАТУ'РА *и. махс.* Квадрат берәмлекләр белән үлчәнә торган мәйданның зурлыгы. *Бүлмәнең квадратурасы. Кечкенә квадратура.*

КВАДРИЛЛИОН *и. мат.* 1 санныннан соң 15 нуле булган сан.

КВАЛИФИКА'ЦИЯ *и.* Кешенең теге яки бу эшкә, хезмәткә яраклылык, хәзерлек дәрәҗәсе; һөнәр, белгечлек. *Төзелеш җитәкчеләре --- кадрларның һич тә җитмәвен, булганнарының да квалификация ягыннан ике аяклап аксауларын басым ясап әйттеләр.* С. Рафиков.

КВАЛИФИКА'ЦИЯЛЕ *с.* Югары квалификациягә ия булган, хәзерлекле. — *Квалификацияле эшчеләрне бер җирдән дә табып булмый, Хәсән Шакирович.* Г. Әпсәләмов. || Төпле, нигезле, бик файдалы. — *Квалификацияле киңәшләр биреп, хәлне төзәтү чаралары тәкъдим итәргә кирәк.* А. Расих.

Квалификацияле хезмәт (эш) — үтәү, башкару өчен махсус хәзерлек, җитештерү күнекмәләре сорый торган хезмәт.

КВАЛИФИКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Квалификация бирү. *Квалификацияләү комиссиясе.*

КВАНТ *и. физ.* Нинди дә булса энергиянең иң кечкенә өлеше яки кисәге. [*Китайгородский*] *С. Н. Вавиловның үз тәжрибәләрендә кеше күзенең хәтта аерым яктылык квантларын да тотып алырга, сизәргә сәләтле икәнлеген исбат итүен искә төшерә.* Соц. Тат.

КВАРТА'Л *и.* 1. Елның дүрттән бер өлеше (өч ай).

2. Шәһәрнең дүрт яктан кисешеп үтә торган урамнар белән чикләнгән өлеше. *Мохтар, өйгә кермичә, янәшә кварталда гына торган Шәрәфи картларга үтеп китте.* Ш. Камал. || Урамның ике чат арасындагы өлеше. [*Шәйхетдинов*] *ярты кварталга сузылган чиратның койрыгына килеп басты.* И. Гази.

3. *махс.* Урман хуҗалыгында билгеле зурлыкта бүленгән квадрат формалы участок. [*Малай:*] *Әти утыз сигезенче кварталга китте. Анда Тукай колхозыннан, урман кисеп, агач чыгаралар.* Э. Касыймов.

КВАРТАЛЛЫК *с.* Бер кварталга билгеләнгән, җитәрлек, бер кварталда эшләнерлек (план, эш һ. б.). — *Хәзер без цех җитәкчеләре алдына шундый таләп куябыз: алар һәрбер эшчегә аның айлык, кварталлык планын кулына бирергә тиешләр.* Г. Әпсәләмов.

КВАРТЕТ *и. муз.* 1. Дүрт тавыш яки дүрт инструмент өчен язылган музыка әсәре. *Студия дәвере татар совет музыкасы үсешендә --- яңа яшь композиторлар үсеп чыгу һәм татар музыкасының күп тавышлы хор, сюита, соната, квартет, симфония һәм опера кебек катлаулы жанрларга баюы белән характерлы.* М. Җәлил.

2. Дүрт кешелек музыкантлар яки җырчылар төркеме. *Баянчылар квартеты.*

КВАРТИ'РА *и.* Торак йортның бер яки берничә бүлмәсе, кухнясы һ. б. лары булган бер өлеше. *Яңа квартира алгач та, өйрәнелгән гадәтен ташламады [Идрис].* А. Гыйләҗев. || Гомумән тору урыны. *Гөлсем апа баш врачның квартирасын эзләп табып, уятып керде.* Г. Гобәй. || Билгеле бер түләү шартларына килешеп, вакытлыча тору урыны. [*Дускаев белән Әминә*] *Нургалилләрдән ерак түгел бер улы һәм килене белән генә тора торган Гөлйөзем исемле карчыкның урам баш өенә квартирага кергәннәр иде.* Ә. Еники.

КВАРТИРАНТ *и.* Билгеле бер шартларга килешеп, вакытлыча квартирада торучы, өйдәш. *Без квартирантлар булып кергән елны Марзия тугызынчы класста укый иде.* Г. Ахунов.

КВАРТИРМЕ'ЙСТЕР *и. хәрби.* Гаскәрләрне азык, квартира белән тәэмин итү эшләреп башкаручы. *Каршы йорттан ак атка атланган адъютант белән квартирмейстер чыгып тауга карап киттеләр.* Ш. Усманов.

КВАРТИРЬЕР *и. хәрби.* Гаскәрләр бер урыннан икенче урынга күчкәндә, алдан барып квартиралар хәзерләп торучы хәрби кеше. [*Алеша*], *квартирьер булып, ерактагы бер авылга киткән иде, аны шунда тотып алганнар.* А. Шамов.

КВАРЦ *и. махс.* 1. Кристалл рәвешендәге төссез минерал.

2. *сөйл.* Кварцлы лампа белән нурландыру. *Кварц белән дәвалау.*

Кварц лампасы — *к.* кварцлы лампа.

КВАРЦИТ *и. геол.* Составында беркадәр башка минераллар катнашмасы булган кварцтан гыйбарәт тау токымы.

КВА'РЦЛЫ *с.* Составында кварц булган. *Кварцлы руда.*

Кварцлы лампа — ультрафиолет нурлар булдыру өчен кварцтан ясалган, кечерәк көпшә формасындагы электр лампасы (медицинада, авыл хуҗалыгында һ. б. кулланыла).

КВАС *и.* Арыш ипиен кызарганчы киптереп, шуннан ясалган эчкелтем эчемлек. — *Менә салкын квас эчеп кенә беседкада гәп корып утырыйк әле.* Э. Касыймов.

КВИ'НТА *и.* **1.** *муз.* Диатоник гаммада бишенче баскыч.

2. *муз.* Кайбер музыка коралларының иң нечкә кылы.

КВИНТЕТ *и. муз.* **1.** Биш тавыш яки биш инструмент өчен язылган музыка әсәре.

2. *муз.* Шундый әсәрне башкаручы музыкантлар яки җырчылар төркеме. *Безнең квартет квинтетка әйләнде, шунда өйрәнер идек* [*ул җырны*]. А. Гыйләҗев.

КВИНТЭССЕ'НЦИЯ *и. кит.* Нәрсәнең дә булса нигезе, төп асылы, эчтәлеге. *Соңгы ике юлны Дәрдмәнд эстетик карашының тозы, квинтэссенциясе һәм Тукайга киңәше дияргә мөмкин.* Г. Халит.

КВИТА'НЦИЯ *и.* Акча яки башка нәрсә кабул итү турында бирелә торган рәсми кәгазь. [*Айсылу:*] — *Илгизәр әнем, бу йөкләрне сиңа ышанып җибәрәм!* — *диде.* — *Бөтенесен тапшырып, квитанцияләрен алып кайт.* Г. Бәширов.

КВО'РУМ *и.* Берәр оешманың җыелышын тулы хокуклы итеп санау өчен кирәк булган катнашучылар саны. *Теләсә нинди мәсьәләне хәл итәргә дә безнең кворум җиткән булыр иде.* Ш. Мөдәррис.

КВО'ТА *и. экон.* Синдикатта яки картельдә катнашучыларның һәркайсы житештерергә яки сатарга хаклы булган товарлар күләме.

КЕБЕК *бәйл.* **1.** Бер нәрсәне икенче нәрсәгә чагыштырып, охшатып әйткәндә кулланыла. *Газинур дары кебек кабынып китте.* Г. Әпсәләмов. *Мамык кебек йомшак кар яуган иде.* А. Шамов. || Берәр төрле эш-хәрәкәткә охшату өчен кулланыла: „сыман, шикелле“ мәгънәсендә. *Ай сөйли кебек бу таңда Яңа ел туачагын һәм аның тагын да матур, Данлырак булачагын.* Ә. Исхак.

2. Берәр нәрсәне шартлы рәвештә чамалап әйткәндә кулланыла. *Берәр җирдән менә кинәт кенә Син чыгарсың кебек шатланып.* С. Хәким. *Дулкын арткан кебек диңгездә.* Ә. Ерикәй. || Берәр нәрсә турында чамалап, икеләнеп әйткәндә кулланыла. [*Нәфисә*] *нәрсәгәдер бик рәнҗегән дә иде кебек.* Г. Бәширов.

3. Берәр нәрсәнең дөреслегенә, булуына шөбһә, икеләнүне белдерү өчен кулланыла. *Хәмдия дип читтә берәү җырлаган кебек булып китте.* М. Фәйзи. *Хуш бул! - - - дигән сүзләре генә колагым төбендә яңгырап киткән кебек булды.* М. Гафури.

4. Бер-беренә нинди дә булса үзенчәлекләре белән охшаш предметларны санап киткәннән соң, шуңа охшаш, шундый ук әйберләр тагы да барлыкны, санарга мөмкин булуны күрсәтә. *Бер як стенага мылтык, кылыч кебек кораллар куелган.* М. Фәйзи.

5. Берәр предметның тулы сыйфатлы булмавын, шул предметка беркадәр якынлыгын гына белдергәндә кулланыла. *Күптән түгел Оренбургтан адвокат кисәге илә бер землемер кебек нәрсәләр килгән иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Кайчак шулай бер-бер иптәшеңдә Утырып, сөйләшер сүз тапмыйсың, Өстәленнән альбом кебеген алып, Рәсемнәрен мактый башлыйсың...* һ. Такташ.

КЕБИ *бәйл. иск. к.* кебек. *И Казан шәһәре, торасың тауда зур шәмдәл кеби.* Г. Тукай.

КЕ'ГЕЛЬ, КЕГЛЬ *и. типогр.* Типография хәрефләренең зурлыгы. — *Д ник* [*башы*] *мондый вак хәреф — уналтынчы кегель белән генә? — дидем.* Ш. Камал.

КЕ'ГЛИ *и. спорт.* **1.** Билгеле бер тәртиптә тезелгән кечкенә таякларны агач шар белән бәрдереп аудару уены.

2. Шушы уен өчен шомартылган кечкенә таяклар.

КЕ'ГЕЛЬБАН *и. спорт.* Кегли уйный торган урын, мәйданчык, бүлмә.

КЕ'ДА *и. спорт.* Брезенттан тегелгән резин аслы, шнурлы җиңел аяк киеме. [*Ренатның*] *аягында кыска кунычлы кедалар.* А. Гыйләҗев.

КЕДР *и. бот.* **1.** Наратлар семьялыгыннан ылыслы мәңге яшел агач. *Ливан кедры.*

2. Чикләвек бирүче кайбер нарат төрләренең халыкта киң таралган исеме. *Себер кедры.* □ *Байкал күле буенда, кедр һәм карагай агачлары арасында „Байкал“ санаториенының матур корпуслары урнашкан.* Соц. Тат.

КЕКС *и.* Майга һәм йомыркага гына изелгән камырга йөзем кушып, төрле формаларга (савытларга) салып пешерелә торган татлы ашамлык. *Рәхим кибеткә кереп - - - ике кекс һәм ике йөз грамм шоколад конфет алып чыкты.* А. Расих.

КЕЛТ: келт итеп искә төшү — *к.* кылт итеп искә төшү. *Каюмның күңеленә келт итеп дхмәт килеп төште.* Ш. Камал.

КЕЛТЕР-КЕЛТЕР *авазияр.* Ритмик тигез тавыш чыгаруны белдерә. *Ап-ак карлар ява җиргә, Уза юлдан чаналар - - - Чаналарны алмаштыра Келтер-келтер арбалар.* З. Мансур.

КЕЛТЕРӘВЕК *с.* Келтерәп торган, тигез, ритмик. *Карт минем янга төшеп корал өйрәнә, келтерәвек тавышы белән бертуктаусыз кабатлый.* С. Баттал.

КЕЛТЕРӘҮ *ф.* **1.** Ритмик тигез тавыш чыгару (мәсәлән, чананың бик җиңел генә шуып баруы, тегү машинасы тавышы һ. б.). *Такыр юлда чана келтерәп кенә бара.* М. Хәсәнов. *Сөмбел бик күңелле итеп кенә келтерәтеп көлеп җибәрә.* Д. Аппакова. || *күч.* Җиңел генә, шома гына бару (берәр эш һ. б.). [*Сәйфи:*] — *Түгел бит хәзер колхозларның элгәрегедәй такыр юлдан келтерәп кенә тәгәрәгән чаклары. Авыр чак, - - - кыен, иптәшләр.* Г. Бәширов.

2. *к.* гөлдерәү. *Кучкылланып кара болыт йөри, Күк келтери, кыя таулар тетри.* Ш. Маннур.

КЕЛТ-КЕЛТ *авазияр.* Сәгать теле йөргән кебек ритмик кабатланып торган тавышны белдерә. *Стена сәгате - - - келт-келт йөреп торды.* Г. Ахунов.

Келт-келт итү — салмак кына ритмик тавыш чыгару (сәгать теленең йөреше турында). *Бүлмә эче һаман буш, тын, беркемнең дә барлыгы сизелми, тик стена сәгатенең бик ачык келт-келт итеп йөргән тавышы гына ишетелә.* Ә. Еники.

КЕ'ЛЬМА *и. махс.* Штукатурлау һ. б. ш. эшләрдә тигезләү, измә сылау һ. б. өчен кулланыла торган тимер көрәк сыман кәкре саплы кул калагы. *Бригадир кельманы кулына алды, измәне ашыкмый гына болгатты.* Б. Камалов.

КЕ'ЛЬНЕР *и.* Германиядә һәм башка кайбер Көнбатыш Европа илләрендә ресторан хезмәтчесе. [*Һадиев*] *нәрсәдер әйтергә теләде шикелле. Ләкин шул чакта кельнер аш китерде.* Ш. Маннур.

КЕЛЬТ *и.* Көнбатыш Европада яшәгән кайбер кабиләләр төркеме атамасы.

КЕ'ЛЬЯ *и.* Монастырьда монах, монахиня яши торган аерым бүлмә яки йорт.

КЕЛӘ *и.* Ишек, капка һ. б. ш. кебекләрнең биге. *Чолан ишегенең келәсе чыңгырдап ачылды.* И. Гази. [*Нәфисә*], *Хәйдәрнең җавабын да көтмәстән, ашыгып капка келәсенә барып тотынды.* Г. Бәширов.

КЕЛӘЙМӘ *и.* 1. Товарда аның сыйфатын, артикулын, эшләп чыгарган предприятиенең исемен һ. б. күрсәткән билге, печать. *Хәзер Сания әзер продукцияне контрольсез, үз келәймәсен сугып кына тапшыра.* Каз. утл. || Яндырып (мәсәләп, хайван тиресенә), сугып (мәсәләп, агач әйберләргә) ясалган тамга. || Гадәттә хәреф формасында җинаятьченең тәненә яндырып ясалган тамга (кайбер илләрдә һәм 1863 елга кадәр Россиядә кулланыла).

2. Келәймә сугу коралы. *Газинур келәймә сабы белән бүреген күтәрә төшә.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Келәймә сугу** — 1) берәр нәрсәнең билгесен, төсен бирү. *Кысык, тар гаилә тормышы эчендә, аннан ярлы үткәрелгән шәкертлек гомере мәдрәсә яшьләренең йөзенә каторга келәймәсе суга.* Г. Ибраһимов; 2) хурлыклы исем бирү.

КЕЛӘЙМӘЛЕ *с.* 1. Келәймә сугылган.

2. *күч.* Начар бер ягы белән танылган, халыкка билгеле (кеше турында).

КЕЛӘЙМӘЛӘНҮ *ф. төш. юн. к.* келәймәләү.

КЕЛӘЙМӘЛӘҮ *ф.* Келәймә сугу. *Әзер мехларны келәймәләү.*

КЕЛӘМ *и.* Идәнгә җәю, стеналарны бизәү һ. б. лар өчен кулланыла торган төрле-төрле төстә, бизәкләп эшләнгән палас. *Идәндә мехлардан шакмаклап эшләнгән келәм җәелгән.* Р. Ишморат. — *Бер келәм сугарлык йоныңны эрләп бирделәр инде.* [*Идәнең*] *җимерелсә, келәм белән капларсың.* М. Фәйзи. || *күч.* Нинди дә булса урынны тоташ каплап алган нәрсә (гадәттә үсемлекләр турында). *Яшел келәм булып калка чирәм, Язгы һава әйбәт булганга.* З. Мансур.

КЕЛӘМЧЕ *и.* Келәм сугучы.

КЕЛӘНЧЕЛ *и. бот.* Ялтырап торган кыяк яфраклы, кар эрү белән чыгып, аксыл шәмәхә чәчәк ата торган суганчалылар семьялыгыннан булган үлән үсемлек; *русчасы:* пролеска.

КЕЛӘТ *и.* Иген салу, төрле нәрсәләр саклау һәм җәй көнендә тору өчен йорт янына яки аннан читкәрәк салынган мичсез махсус бина. *Дни ак келәткә бик әйбәтләп урын җәеп куйган.* Ф. Хөсни. *Колхозның уңышы елдан-ел арта барганда, иске келәтләр, иске базлар гына аны канәгатьләндерә алмый иде.* Г. Әпсәләмов.

КЕЛӘТЧЕ *и. к.* кладовойчы. *Колхозның Югары Тегермәнлек авылындагы келәтчесенә кереп яхшы гына сыйланып та чыкканлыктан, аның йөрәгә ярсулы иде.* С. Рафиков.

КЕЛӘШЧӘ *и.* Нәрсәне дә булса кыстырып алу һәм суырып чыгару һ. б. лар өчен хезмәт итә торган кыскыч формасындагы металл инструмент. *Юлдаш бабай ишарәләүгә,* [*Зөһрә*] *тимерне учактан келәшчә белән кысып алып сандалга куйды.* Г. Гобәй. *Корбан күп вакытта ялгызы гына эшли: бер кулында келәшчәгә кыстырган сабан күчәре.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

◇ **Келәшчә кебек** — бик каты. *Кемдер арттан килеп үзенең келәшчә кебек куллары белән мине әләктереп, кочаклап күтәреп тә алды.* Ә. Айдар. **Келәшчә белән тартып алу** (сүзне) — аз сүзле кешене бик авырлык белән генә сөйләтү. *Әйтсә, берәгәйле әйтә, әйтмәсә, сүзен авызыннан келәшчә белән дә тартып ала алмыйсың.* Ш. Рәкыйпов.

КЕЛӘҮ *и. диал. к.* гыйбадәт. *Болгармы бу, келәү йортымы, Тулган җыен кирәмәт имчесе.* Н. Исәнбәт. — *Әле ни бәйрәм, ни келәү, тиле кызның туедай, тик торыштан эчеп утыруны кайдан уйлап чыгардың?* Г. Камал.

Келәү итү — гыйбадәт кылу. [*Татарларның юраулары буенча*] *астында келәү ителә торган агачны, мәсәлән, чуваш кирәмәтен кисәргә ярамый.* К. Насыйри.

КЕЛӘҮЛЕК *и. диал.* Гыйбадәт кылу урыны. *Куе нарат эчендә бу алан — Ак бүре ыруының келәүлеге, келәүлек уртасындагы изге нарат — Ак бүре ыруының табына торган изге нараты иде.* Н. Фәттах.

КЕМ *а.* 1. Нинди яки кайсы кеше икәнен белергә теләп сораганда кулланыла. *Кем соң кычкырды?* Т. Гыйззәт. *Кемгә соң ул бүләк?* К. Тинчурин.

2. Нинди кеше, нинди эш белән шөгыльләнүче һ. б. булуын ачыклау мәгънәсендә килә. *Кыз, үз нәүбәтендә, минем кем булуым, кая баруым белән кызыксынды.* Ә. Еники. || Якын таныш, берәр үз иткән кеше. [*Заһид Мәдинәгә:*] *Минемчә, сезнең кемегез булса да бар.* А. Расих. || *Дә* кисәкчәсе янында *беркем, һичкем* алмашлыклары мәгънәсендә килә. *Ай йөзәдер күк йөзендә, Кем дә кайгыртмый аны.* Ф. Бурнаш. *Минем авыр язмышымны Кем дә күрмәсен иде.* М. Җәлил.

3. *Дә, менә* алмашлыклары белән килеп, нәрсәне дә булса аерып күрсәтүне, басым ясап әйтүне белдерә. *Менә кем ул безнең командующий!* Г. Бәширов. *Менә кем икән ул йортымдагы чүлмәкләрне харап итүче!* Һ. Такташ.

4. Ике яки берничә җөмләнең һәрберсендә килеп, бүлгәләү мәгънәсен белдерә: *берсе, икенчесе* (икенчеләре), *кайсы* (кайсылары). *Кем чаба, кем көлтә бәйли, — Барысы да алга бара.* Ә. Исхак. *Фронтовикларга дип атап, кем оекбаш, кем җылы бияләй бәйли.* Г. Әпсәләмов.

5. Риторик сорауларда һәм өндәү җөмләләрдә *теләсә кем, һәркем* мәгънәсен белдерә һәм хәбәр булып килгән фигыльнең киресе эшләнүен аңлата. [*Мәгъсүмә:*] — *Мин өяз тарафыннан куелган мөгаллимә, минем яныма кем килмәс!* И. Гази. *Кем кызганыр изге көчен Кадерле Ватан өчен?* Ә. Ерикәй.

6. *мөн. сүз. бәйл. функ.* Баш җөмләдәге *ул, шул* сүзе белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен ия җөмләне баш җөмләгә бәйләү өчен кулланыла. *Кем кашык тоткан, Шул кабып йоткан.* М. Җәлил. *Кем ашык уйнаганы бар, ул белә: иң кызыгы, әлбәттә - - - ашыклар өстенә беренче булып бәрү.* Ә. Фәйзи. || Кушма җөмләдә кире җөмлә составында килеп, баш җөмләдәге *барыбер* сүзе белән бергә иярчен кире җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Кем булсаң да (кем генә булма), барыбер...*

7. Кабатлаулы формада төрле килешләрдә: *кем-кем, кем-кемне, кем-кемгә, кемнән-кемнән* һ. б. Кемне дә булса үз ишләреннән аерып күрсәтү өчен кулланыла. *Кем-кем син дә шулай дисең инде.*

Кем белә — билгесезлекне аңлата. *Кимендә җидесигез кеше булып чыкты. Кем белә, бәлки, уннан да артыктыр.* А. Шамов. *Кем белә, бәлки, ул аны туганы итеп, кызганып, үз авызыннан өзеп биргәндер.* Г. Гобәй.

КЕ'МБРИЙ *и. махс.* Палеозой эрасының беренче чоры. *Кембрий токымнары белән көч сынашырга ашкынып килгән Татарстан бригадаларына беренче көннән үк үзләре теләгән, яраткан эшләренә тотынырга туры килми.* Ә. Маликов. *Булат Дияров Себер нефтен, кембрий нефтен ачарга китә.* Г. Ахунов.

КЕМДЕР *а.* Ниндидер, кайсыдыр, билгесез кеше, берәү. *Кемдер, дежурный булса кирәк, яралыларны тыныч ландырмакчы була.* А. Шамов. *Арырак, су буенда кемдер берәү җырлый.* М. Фәйзи.

КЕМЛЕК *и.* Кем булу, нинди кеше булу. *Бик күпләрнең, әйтик, кемлекләрен Еллар буе белми барасың, Кинәт бер вакыйга уртасында күреп, Аның кемлегенә хәйран каласың.* Һ. Такташ. *Аннан соң* [*Исагулов*] *минем кемлегемне, ата-аналарымны, аларның кәсепләрен сорашты.* Ә. Фәйзи.

КЕМСӘ *а. иск.* 1. *к.* кем. *Көтәм, ярдәмгә һичбер кемсә килми.* Г. Тукай.

2. *к.* кеше. *Җавабын бирә алмаса, түләргә акчасы булмаса, Банкрот булыр ул кемсә.* Ш. Мөхәммәдев. *Биш кемсәдән гыйбарәт махсус комиссия сайладылар.* Ә. Исхак.

КЕМӘЙ *и. диал.* Дус, сердәш. *Кызның кемлеге кемәеннән күренә.* Мәкаль.

КЕНАФ *и. бот.* Мальвалар семьялыгыннан җепселе текстиль чималы буларак кулланыла торган берьеллык көньяк үлән үсемлеге. *Көньяк Казахстанда кенаф, көньяк киндере күп игелә.* СССРның экон. геогр.

КЕНДЕК *и.* 1. *анат.* Кеше яки хайван яралгысын ана организмы белән тоташтыра һәм яралгыны тукландыру каналы булып хезмәт итә торган көпшә. [*Зәйтүнәнең*] *түтәе баланың кендеген кисте.* Ф. Хөсни.

2. Корсак уртасындагы кечкенә генә батынкы урын (кендекне кискәннән соң калган җөй). || Гомумән кендек урнашкан урын, шул тирә. [*Харисның*] *бөтен киеме бер чалбардан гыйбарәт булып, --- үзенә бик зур, кендектән әллә никадәр югары күтәртеп кигән булуга карамастан, балагы җир себереп йөри.* Г. Гобәй.

3. Арбага алгы күчәрне тоташтырып куя торган тимер таяк. *Йөкче дә арба кендеге алып, каракка каршы торды.* Г. Тукай. || Капка бикли торган тимер таяк. *Апай капканың аркылы тыккан кендеген тартып эчкәре узды.* Ә. Еники.

4. *күч.* Нәрсәнең дә булса үзәге, иң әһәмиятле урыны. — *Беләсезме, — дип куйды* [*Шәмси*], *бүгенге сугышның кендеге Перекопта бит!* Г. Бәширов. [*Ислам:*] — *Дөньяның кендеге монда гына түгелдер әле, китәргә, кая да булса күз күрмәс, колак ишетмәс җиргә.* Н. Фәттах. || Кирәкле, күренекле кеше турында. *Хаҗи әфәндене шәһәребезнең кендеге дип әйтеп була.* Ш. Камал. *Икенче берәүләр дәрәҗәгә ирешеп алсалар, үзләрен әллә кем дип, дөньяның кендеге дип уйлый башлыйлар.* Г. Ахунов.

Кендек бавы — *к.* кендек 1. **Кендек әбисе** — бала тудыру вакытында ярдәм күрсәтүче, бала кабул итүче карчык. *Кендек әбие булмаган Минем туган чагымда.* Ә. Ерикәй. *Кендек әбиләр гасырлар буена изге эш эшләгәннәр — йөкле хатыннарга булышлык күрсәтә килгәннәр.* Н. Фәттах.

◇ **Кендек бәйләнү (ябышу)** — билгеле бер нәрсәгә, урынга ныклап урнашкан булу, бәйләнгән булу. *Бер нәрсә бик ачык: барысының да кендекләре авылга бик каты бәйләнгән, ай-һай, куптарып алып китеп булырмы?* И. Гази. *Кендегебез ябышмаган иҗ аларга, киттек, мин әйтәм.* К. Нәҗми.

КЕНӘ *кис. к.* кына. *Бу урман әрәмәлек кенә иде.* М. Гали.

КЕНӘГӘ *и.* Нинди дә булса мәгълүмат алып бару өчен бер төпкә төпләнгән кәгазь битләре, катыргы тышлы дәфтәр. *Хәлфә берәм-бәрәм* [*балаларның*] *исем-фамилияләрен сорады һәм аларны кенәгәгә терки барды.* Ә. Фәйзи. [*Әхмәтсафа ага*] *барлык алачак-бирәчгән, алган-сатканын һәм тоткан расходын яшел тышлы бер кенәгәсенә карандаш белән язып куядыр.* Ш. Мөхәммәдев. || Нинди дә булса текстны һәм төрле рәсми билгеләр өчен урыны булган төпләп эшләнгән документларның исеме. *Китапханә кенәгәсе. Кызылармеец кенәгәсе.* □ [*Мөнәвир*] *хезмәт кенәгәсен тотып Сәләхетдин абзый янында утыра.* Ш. Бикчурин. *Шатлыктан күзләре нурланып киткән студент кабаланып зачет кенәгәсен сузды.* А. Расих.

КЕНӘР *и. иск. к.* яр II.

КЕНӘРИ *и. зоол.* Сары йонлы, бик матур сайрар кош (бүлмә кошы буларак таралган). [*Хөсәен карт*] *өендә гөлләр күп була, ике тәрәзәсенә дә эленеп куелган читлекләрдә ике кенәрие дә була.* Г. Газиз.

КЕ'ПКА *и.* Ирләрнең козыреклы баш киеме. *Битләренә корым ябышкан, кепкаларының козыреклары артка әйләндереп кигән шаян слесарьлар Газинурның йөрәгенә бик нык кереп урнашканнар.* Г. Әпсәләмов. [*Илдар*] *кепка козырегын борын очына хәтле төшергән хәлдә тик аска карап утырды.* Г. Гобәй.

КЕ'ПКАЛЫ *с.* Кепка кигән. [*Түбәннән*] *берсе шлемлы, берсе соры кепкалы ике баш калыкты.* Г. Ибраһимов.

КЕР *и.* 1. Юылган яки юылырга тиешле өс-баш киемнәре һәм тукымадан тегелгән төрле көнкүреш кирәк-яраклары. *Беркөнне* [*Рәүфә*], *Гөбенгә кер чайкарга баргач, дусты Бануны очратты.* А. Шамов. *Киптерү өчен читәнгә эленгән кернең бөрсе, җил белән очып, чирәмгә төшкән.* И. Гази. *Миңсылу кер тукмаклый.* Һ. Такташ. || *с. мәгъ.* Кер юу өчен билгеләнгән. *Форточка ачык булуга карамастан, бүлмәдә тәмәке төтене катыш --- кер сабыны исләре аңкый.* Ш. Камал.

2. Пычрак тап (тәндәге, киемдәге һ. б.). *Гөлсем апа --- баланың муенындагы керне күргәч, чишендереп, юыну бүлмәсенә алып керде.* Г. Гобәй. [*Сәрвәр:*] *Кер тидермәм бер җиренә,* [*башмакларны*] *салгач, куям өстен каплап.* Т. Гыйззәт. || *күч.* Начарлык, начар як (күңелдәге, намустагы). *Бу төнне мин, синең турыңда уйлаганда, сиңдә бер генә дә кер, начар як күрмәдем.* Г. Кутуй. *Тышлары керле, вә ләкин юк аларда әч кере.* М. Гафури.

◇ **Кер куну (төшү)** — 1) пычрану, каралу; 2) *күч.* таплану (намус, күңел һ. б.). *Хәсәнгә булган шул якты тойгыга заман һәм тормышның иң болганчык шартлары да кер кундыра алмадылар.* К. Нәҗми. **Кер күтәрә торган** — тиз керләнми, керләнгәне беленми торган (мәсәлән, кием).

КЕРА'МИК *с.* Керамикадан (3 мәгъ.) эшләнгән, керамикадан ясалган. *Кызыл, сары керамик плиталардан җәелгән идәнгә зур тәрәзәләрдән кояш нурлары төшкән.* Соц. Тат.

КЕРА'МИКА *и.* 1. Чүлмәк-кирпеч производствосы.

2. *җый. и.* Балчыктан ясалган әйберләр. *Иске Казан урынынан җыелган керамика һәм Мишә буендагы аерым табылдыклар* [*болгарлар килүенә*] *дәлил булып тора.* Каз. утл.

3. *махс.* Шундый әйберләр ясау өчен кулланыла торган масса. *Соңгы вакытта радиотехникада слюдалы конденсаторлар урынына керамикалы конденсаторлар кулланыла башлады.* Физика.

КЕРАТИН *и. биол.* Составында күкерт булган аксым матдәсе (чәч, тырнак, тире һ. б. ларның состав өлеше).

КЕРАТИТ *и. мед.* Күздәге мөгезсыман катлауның ялкынсынуы.

КЕРГЕЗИН *и.* Юка мамык тукыма. *Миңа бирәр бишмәт алсалар, нинди күңелле булыр иде дип, кызыл кергезин бишмәтемне күз алдыма китерәм.* М. Гафури.

КЕРДЕЛЕ-ЧЫКТЫЛЫ *с.* 1. Бормалы, төз түгел. *Керделе-чыкты урам.*

2. *күч.* Принципсыз, үз карашы булмаган, тәртипсез (кеше турында). *Керделе-чыктылы кеше.* □ — *Җәгъфәрнең керделе-чыктылы булуына нәрсәгә гаҗәпләнәсең?* Г. Әпсәләмов.

3. *к.* килделе-киттеле. *Баштагы керделе-чыктылы уйларны таратып кайту --- өчен* [*Маһирәләргә*] *киттем.* Ф. Хөсни.

КЕРДЕШ *и. диал.* **1.** Йортка кергән ир.

2. *күч.* Семьяда чит кеше, читтән килеп вакытлыча гына яши торган кеше, килмешәк.

КЕРЕМ *и.* Дәүләт, сәүдә-промышленность учреждениеләре, аерым кешеләр һ. б. ш. тарафыннан нинди дә булса эшчәнлек нәтиҗәсендә алына торган акча һәм материаль кыйммәт, табыш. *Керем бар җирдә чыгым бар.* Мәкаль. *Төрле оешмаларга машина белән йөк ташып табылган акчаларны һәм башка керемнәрне кушкач --- халык күңелен күтәреп җибәррелек акча тупланды.* А. Расих. || Бухгалтерия кенәгәсендәге акча һәм материаль кыйммәтләр табышын язып бара торган графа. *Квартира өчен түләү акчаларын керемгә алу.*

КЕРЕМ-ЧЫГЫМ *и.* Кергән һәм тотылган акча һәм материаль кыйммәтләр. [*Гөлнур*] *иртәнге якта --- теге узган елгы керем-чыгым кенәгәләрен алып чыгып китте.* М. Хәсәнов.

КЕ'РЕНКА *и. сөйл.* Башында Керенский торган Вакытлы хөкүмәт чыгарган кәгазь акча. *Хуҗа, хәерсәдакаларын өләшкәндә, Шәйхигә 2д сумлык керенканы төртте.* И. Туктар.

КЕРЕНТЕ *и.* Кереп торган, уелып кергән урын. *Кембрий катламнары Фин култыгының яр керентесен тәшкил итәләр.* Үтк. зам. сәяхәт.

КЕРЕНТЕЛЕ-ЧЫГЫНТЫЛЫ *с. к.* керделе-чыктылы 1.

КЕРЕШ I *и. сөйл.* Керү фигыленнән ясалган исем. *Барып керешенә туп-туры: „Дни кайчан үлде?" — дип сораган* [*Гали*]. Г. Коләхметов.

КЕРЕШ II *и.* **1.** Җәя җебе. [*Идегәй укны алып:*] *Аны шушы җәя белән королеңә тапшыр. Тартып карасын. Керешен җиткерә алса, безнең белән сугышырга килсен.* Н. Исәнбәт.

2. *диал.* Резинка (оек тоткыч). *Өскны түгәрәк кереш белән киярга һич тә ярамый.* Азат хатын.

3. *анат.* Тел астындагы яры (кайбер балаларда була, сизелгәч тә аны кисеп җибәрәләр, чөнки ул имәргә, ә теле ачыла башлагач, сөйләшергә комачаулый).

КЕРЕШ III *и.* Әдәби һәм музыкаль әсәрләрнең, доклад һ. б. ларның башлангыч өлеше, төп өлешкә кадәр булган кисәге. *Спектакльнең әкиятчә кереш белән башлануы һәм әкиятчә соңгы сүз белән бетүе дә урынлы.* М. Җәлил. | *с. мәгъ. Дирижер чыбыгын селтәп җибәрде, оркестр кереш музыканың беренче моңнарын сыза башлады.* Ш. Хөсәенов. *Хикәядә озын кереш бүлекләр дә, сүз ахыры да юк.* Г. Нигъмәти.

Кереш сүз — 1) башлангыч сүз, сүз башы. *Маннурның шул кичәдә сөйләгән кереш сүзен Казаннан, радиодан килгән корреспондент хәтта магнитофон лентасына язып алды.* М. Хәсәнов. 2) *лингв.* сөйләүченең җөмләдәге уйга мөнәсәбәтен күрсәтү өчен кертелгән сүз. **Кереш җөмлә** *лингв.* — сөйләмдә әйтелгән фикерне сүз арасында ачыклап китү, сөйләм барышында искәрмә ясауны белдергән җөмлә.

КЕРЕШЛЕ I *с.* Сыя торган, сыешлы. *Аннары бервакытны, бодай туфракны каплап бетермәс борын, Яурышкан буена кырык чиләк кергшле зур мичкә җигеп килделәр.* Г. Бәширов.

КЕРЕШЛЕ II *с.* Керә торган. *Өйнең ике ишеге бар, икесе дә террасадан керешле.* Д. Аппакова.

КЕРЕШЛИ *рәв.* Кая да булса кергәндә, керү уңаенда. *Шофер машинасына керешли: „Белеп сайлагансыз, достойный егет", — дигән булды.* Г. Гобәй.

КЕРЕШҮ I *ф.* **1.** Берәр нәрсә эшли башлау, эшләргә тотыну. *Солдатлар елга буйлап окоплар, блиндажлар казырга керештеләр.* Ә. Айдар. *Бар да тынып калдылар, ә Кәримә йомшак, ягымлы тавышы белән гадәттәгечә каушабрак сөйләргә кереште.* Ә. Еники.

2. *күч. юкл. форм.* **керешмәү.** Кагылмау, нинди дә булса мәсьәләне читләтеп үтү. — *Исереклек беләнме, түгелме, мин анысына керешмим, әнә минем балам, яныма да кермичә, урамда йөри.* Ф. Бурнаш.

КЕРЕШҮ II *ф.* Бер-беренә керү, йөрешү. *Күрше белән керешү.*

КЕРЕШҮ III *ф.* **1.** Укмашу, киезләнү (йон, киез һ. б. әйберләр турында). *Ак тулалар тиз керешә, аркау-буе тигез эрләнсә.* Җыр.

2. *күч.* Кушылу. *Аерым кабилә телләренең үзара керешүе.* □ *Телдәге стильләр бер-береннән бөтенләй аерым-аерым яшәмиләр, үзара үрелеп, керешеп кулланылалар.* Сов. мәкт.

КЕРЛЕ *с.* **1.** Пычрак, каралган, чиста булмаган. *Җаббар абзый ябынып ятканкерле, сәләмә юрган астыннан башын күтәрде.* Ә. Фәйзи.

2. *күч.* Начар, усал (ният, күңел һ. б.). [*Сугышчыларда*] *кызга карата һичбер керле, пычрак уй булмый.* А. Әхмәт. *Керле кеше мин, — диде ул сүзенең азагында, — җаным керле минем.* Г. Гобәй.

КЕРЛЕЛЕК *и.* **1.** Керле булу, пычранган булу (кием һ. б.). *Бу курчак бүлмәгә аяк басуым белән үк өстемдәге киемемнең керлелеген, аягымдагы итегемнең тузанлылыгын сизеп алдым.* А. Шамов.

2. *күч.* Начарлык, усаллык. *Күңел керлелеге.*

КЕРЛӘҮ *ф.* **1.** Пычрану, каралу. *Гимнастёрка керләнгән, итекләр искергән, ияк буйларын йон баскан, чәчләр тигезләнмәгән.* Ш. Камал. [*Полиграфистларның*] *куллары, битләре кургаш тузаны белән керләнгән.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Таплану, пычрану (исем, мәхәббәт һ. б.). *Кайтмады үч, беттә көч, сынды кылыч — шул булды эш. Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.* Г. Тукай.

КЕРН *и. махс.* Җир бораулаганда төрле тирәнлектән тикшерү өчен алына торган токым. *Рәхимә белән Нарский бүлмәдә, өстәл артында скважинадан алынган керннарны тикшереп утыралар.* А. Әхмәт. [*Миргали*] *--- төрле төстәге ташлар һәм керннар тутырылган тартмаларны күрде.* М. Хәсәнов.

КЕ'РНЕР *и. махс.* Детальләргә билге, эз ясау өчен кулланыла торган конус сыман очлы, кыска гына **корыч** инструмент. [*Смирнов*] *түгәрәк сызыклар ясый, шунда ук түгәрәкләрнең нәкъ уртасына карандаш кебек очлы корыч кернер белән эз төшереп куя.* А. Расих.

КЕРОГАЗ *и.* Керосин парлары янып кызулык барлыкка китерә торган прибор (тавышсыз примус төре).

КЕРОСИН *и.* Нефтьне кудырып алына торган сыек ягулык. *Яндырырга лампаның керосины беткән.* М. Гафури.

КЕРОСИ'НКА *и.* Керосин янып кызулык барлыкка китерә торган филтәле прибор. *Гөлсем апа --- керосинканы кабызып эшкә кереште.* Г. Гобәй.

КЕРПЕ *и.* **1.** *зоол.* Аркадагы һәм яндагы тиресе әнәләр белән капланган кечкенә генә җәнлек. [*Керпене*] *бер әнәсеннән чеметеп күтәрдем дә зур чиләктәге суга салдым.* Г. Мөхәммәтшин. *„Скважиналар карап йөргәндә, урманда берсе очраган иде, карт керпе булып чыкты, әнәләрен тырпайтты да йомарланып ятты", — диде* [*нефтьче*]. Г. Ахунов. || *күч.* Чәнечкеле, усал сүзләр әйтүче кеше турында.

2. *хәрби.* Танклар һәм пехотаны тоткарлап тору өчен чәнечкеле тимер чыбыклар белән уратып алынган аркылы-торкылы казыклардан торган корылма. *Каланың бөтен әйләнәсе Кырык катлы „корыч керпе".* Ш. Маннур.

КЕРПЕЛӘНҮ *ф.* Усаллану, кырыслану, бик төксе сөйләшү. [*Зөбәржәт:*] — *Син бүген иртәдән бирле керпеләнеп йөрисең, минем белән күңелсездер шул.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

Керпеләнеп кыскартылган (алынган) — бик кыска калдырып алынган (чәч турында). [*Бәк-Бәкчи*]*нең чәче керпеләнеп кырылган булыр, ияк ялтырап тора.* Х. Кәрим.

КЕРСЕЗ *с.* **1.** Чиста, пычранмаган, буялмаган (кием, тән һ. б. лар). *Киеменең очсызлы һәм искерә төшкән булуына карамыйчан, керсез, тузансыз булуы — әүвәлге карашымнан ук бу татарны миңа сөекле күрсәтте.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Саф; чын, риясыз. *Керсез дуслык, тирән сөю хисе Безгә матур бәхет китерсен!* М. Җәлил. *Әллә кайдан, тирәннән, керсез йөрәктән чыккан төсле булып ишетелде ул рәхмәт.* М. Әмир.

КЕРСЕЗЛЕК *и.* **1.** Чиста булу, пычранмаган булу, буялмаган булу (кием, тән һ. б. ларның).

2. *күч.* Сафлык, саф булу, риясыз булу: [*Укчыларның*] *барысының да йөзләрендә сафлык, керсезлек!* А. Әхмәт.

КЕРТ *аваз изл.* Күбесенчә кабатлап әйтелә (керт, керт). Нәрсәне дә булса кискәндә, тапаганда һ. б. ш. очракларда ишетелгән тавышны белдерә. *Пыяла керт иттереп кителгәч кенә, һади җиңел сулады.* А. Гыйләҗев. *Ат тояклары керт-керт итеп, нәрсәдер тапаган авазлар чыгаруы аерым-ачык булып ишетелә.* М. Хәсәнов. [*Ат*] *сусыл, йомшак, хуш исле үләнне әкрен генә керт-керт кимерә иде әле.* Г. Гобәй.

КЕРТҮ *ф.* **1.** *Йөк. юн. к.* керү 1, 4, 5, 12, 14, 16.

2. Керергә рөхсәт бирү, үткәрү. [*Егет:*] *Әгәр бөзне анда* [*клубка*] *кертәләр микән соң?* Ф. Бурнаш. *Муенына кызыл галстук бәйләгән яланаяклы кечкенә кара малай басу капкасын ачып кертте.* Г. Ибраһимов. || Үтәргә мөмкинлек бирү (су, суык, җил һ. б. ларга). *Ана белән кыз арыкны тазартканнар, буасын ачып аңа саф су агызып керткәннәр.* Д. Аппакова. — *Ишекне ябыгыз тизрәк, суык кертәсез!* — *дип кычкырды бер хатын-кыз.* Ә. Фәйзи.

3. Кемне яки нәрсәне кая да булса алып керү, урнаштыру. *Гафифәне кертеп яткырдылар.* Ш. Камал. *Килеп тукталуга, Габделнасыйр арбадан сикереп төште дә, капканы ачып, атны ишек алдына кертте.* М. Гали.

4. Исемлеккә, берәр нәрсә исәбенә теркәү, составына билгеләү. *Үзара сүз көрәштерергә тотындык: көтүче Сахауларны, Камилә әбиләрне йорт исәбенә кертергәме, юкмы.* Г. Гали. *Нәфисә бригадасы үзенең арышын, бүгенге кертеп, өч көн эчендә урып бетермәкче була икән.* Г. Бәширов. || Берәр нәрсә белән тиңләштерү, нинди дә булса дәрәҗәгә житкерү. *Алексей Федорович, без соң Татарстанны „икенче Баку"га кертер өчен йөрибез түгелме?* А. Әхмәт.

5. Нәрсә дә өчен булса түләү, бирү. [*Ифрат Бәһавига:*] *дә Солтан дөрес әйтә: колхоз кассасына акча кертсәң — рәхим ит!* А. Расих.

6. Берәр нәрсәне гамәлгә ашыру, урнаштыру, законлаштыру. *Буржуазия тылда да үлем җәзасы кертүне таләп итә.* И. Гази. *Бездә хәзер композитор белән авторның --- оперетта тудыру гадәтен тәҗрибәгә кертергә кирәк.* М. Җәлил.

7. Берәр нәрсәгә билгеле бер төс, кыяфәт һ. б. бирү, аны билгеле бер рәвешкә китерү. *Яралының ярты як битенә генә ут шәүләсе төшеп, аны тагын да кызганычрак кыяфәткә кертте.* Г. Гобәй. *Ләкин фронт ягыннан кайткан отрядларның вәкилләре мәсьәләгә башка төс керттеләр.* Ш. Усманов.

8. Үткәрү, урнаштыру (электр, су, телефон һ. б.). *Ут керту. Газ керту.* □ *Кухняларга калын итеп су трубалары керткәннәр.* Г. Гали.

9. Абстракт исемнәр белән янәшә килеп, шул исемнәр белдергән хәл, күренешкә дучар ителүне аңлата. *Төзәтмә керту. Өстәмә керту.* □ *Шәкертләрнең һәркайсы, Габдулла кебек, бер үзгәреш кертте.* Ә. Фәйзи.

КЕРФЕК *и.* Күз кабаклары читендәге күзне саклаучы төкләр. *Газинур бозланып ябышкан керфекләрен бармагы белән эретеп күзен ачты.* Г. Әпсәләмов. *Абау, җаным, керфегең, Бирче миңа бөртеген.* Җыр.

◊ **Керфеген дә селкетми** — исе дә китми. *Нәфисә, кичтән Зиннәт узганда кая басарын, нишләрен белмичә үзәге өзелеп калса да, иртәгесен очрашкан вакытта керфеген дә селкетми иде.* Г. Бәширов. **Керфек тә какмау** — йокламау. *Ифрат әлегә кадәр керфек тә какмый, борчылып үзен көткән Тәнзиләсе янына чыкты.* А. Расих.

КЕРФЕКЛЕ *с.* Керфекчекләр белән капланган. *Керфекле инфузорияләр.*

КЕРЧӘН *с.* Тиз керләнүчән. *Кеше киемә керчән, кеше аты тирчән.* Әйтем.

КЕРШӘН *и.* Пудра. *Зөлсәгыйдә кершән ягынырга керешә.* Т. Гыйззәт.

КЕРШӘН-ИННЕК *җыйг. и.* Гомумән бизәнү-сөртенү әйберләре. *Иртә белән көтү куган вакытта торып чәй эчәбез дә кырга китәргә әзерләнәбез, кай арададыр теге* [*Мифрижамал*] *кершән-иннекне ягынып, читек-рәжинкәне киеп алган.* М. Гали.

КЕРӘЛЕ: керәле дә чыгалы — *к.* **керделе-чыктылы.**

КЕРӘН *и. бот.* **1.** Тамыры аш тәмләткеч булып кулланыла торган әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан булган үсемлек. [*Малайлар*] *бакчаны керән тамырларыннан тазартырга ябыштылар.* Э. Касыймов.

2. Шушы үсемлекнең ачы тамыры һәм шуннан хәзерләнгән аш тәмләткеч. *Пешкән ит, кыздырылган каз, койка керән белән бик тәмле.* Азат хатын.

КЕРӘҖ *и. диал.* Фарфор, фаянс, чынаяк. *Керәҗ кирпеч.* □ *Чыбыкның икенче очын мунча артында кукыраеп утырган өянке ботагындагы керәҗ кәтүккә бәйләделәр.* Г. Мөхәммәтшин.

КЕРӘШЕН *и. этн.* Христиан динен кабул иткән татар. *Мин башта татарча сөйләшкән „маржалар"ны күреп гажәпләнсәм дә, соңыннан боларның приискадан өч чакрым жирдә булган керәшен авылының хатын-кызлары икәнлекләрен белгәч, --- [аларның] кемнәр икәнен төшендем.* М. Гафури.

КЕРӘШӘ *и. зоол.* Очлаеп киткән озын канатлы кечерәк кош; яр карлыгачы. *Дәрәмә артындагы текә ярдан* [*Исхак*] *Сәниягә керәшә балалары алып күрсәткән иде.* А. Гыйләҗев.

КЕРҮ *ф.* **1.** Берәр нәрсәнең эченә таба хәрәкәт итү, кая да булса үтү, берәр нәрсәнең чиген үтү. *Беренче малай --- yрылмаган җир өстенә кереп китте.* И. Гази. *Шәһәрнең икенче ягыннан кечкенә төркемнәргә бүленгән казак отрядлары керделәр.* Ш. Усманов.

2. Берәр нәрсәнең эченә үтү; кадалу. *Сабан жиргә керми, читкә тайпылып чыга.* М. Гафури. *Илдар бармагына кергән шыпыны әнисеннән алдырта да сүзен дәвам итә.* Г. Гобәй. || Эчкә үтү, кая да булса юл табып үтү, түлү (су, суык, жил, тузан һ. б.). *Күптән инде, ватык тәрәзәдән Яңгырлы жил керә бүлмәгә.* Ш. Маннур. *Ә тирә-якстагы таулардан урам уртасындагы чокырга ургылып-ургылып су керә.* Г. Әпсәләмов.

3. Берәр максат белән яшерен рәвештә үтү (өйгә, бүлмәгә һ. б.). *Безгә бүген бур кергән иде.* Ш. Камал. [*Мәрьямгә әнисе:*] *Монда бер кеше дә юк, торып киен дә бу якка чык... Кеше-кара кермәсен!* Г. Ибраһимов.

4. Урнашу, кабул ителү (эшкә, уку йортына һ. б.). *Әминә шәһәр больницасына медицина сестрасы булып кичке сменага эшкә керде.* Г. Минский. *Мәдинә фронтлар тынгач кына, - - - кемнеңдер димләве буенча педагогия курсларына керә.* К. Нәҗми. || Берәр нинди оешма, җәмгыять членына әверелү. *Комсомолга керү. Партиягә керү.* □ *Колхозга кергәч, Гафиятулла бабай берме-икеме җәй колхоз көтүен көтте.* Г. Әпсәләмов.

5. Билгеле бер вакытка дәвалану өчен яту, урнашу (больницага, госпитальгә һ. б.).— *Анда бер-ике көннән терелтерләр, без сине көтеп торырбыз,— дигәч, Нәҗип, нидәяттъ, больницага керергә риза булды.* Г. Гобәй. || Хөкем ителү, утыртылу, ябылу (төрмәгә). [*Гали*] *төрмәгә кергән.* Г. Коләхметов.

6. Берәр нәрсәнең составында саналу, составына билгеләнү. *Хөкүмәт составына керү.* □ *Айсылу соңгы көннәрдә үз авыл Советына керә торган күрше „Алмалы" колхозында эшләде.* Г. Бәширов. || Кая да булса теркәлү, язылу, исәпкә алыну. *Исемлеккә керү,* □ *Син, Габдулла агай, опись кәгазенә кергән әйберләрне сатмаска тиешлесең.* Һ. Такташ. || Искә алыну, берәр нәрсәнең состав өлешенә әйләнү. *Докладка керү. Приказга керү.* □ *Җыентыкка кергән мәсәлләрнең бер өлеше Тукайның үзе язып куйган мораль нәтиҗә чыгарулары белән оланганнар.* Г. Нигъмәти. *Бишенче номер [„Совет әдәбияты"] чыккан, диләр. Минем ике шигырем кергән, диләр.* М. Җәлил.

7. Савытның сыешлылыгы турында. *Банкага бер литр керә.*

8. Җитү, башлану (календарь ай, төрле сезон һ. б.). *Әмма январь керү белән, Шәмгун карт ул көннән кайтты.* А. Шамов. *Печән өсте яңа керде.* М. Гафури.

9. Билгеле бер күренеш, вакыт арасын һ. б. үтеп, тәмам итеп, икенче бер күренеш, вакытка һ. б. күчү. *Умарта корты җәй буенча чәчкәләрдән бал җыя, кышка керсә, кыш буенча уңартасында хәл жыя.* М. Гафури. *Кичкә керсәм, тыныч йокы теләп, Күзләремә сөеп караучы Син түгелме, кояш!* М. Җәлил. *Минем Алмачуар өченчегә [яшькә] керә.* Г. Ибраһимов.

10. Билгеле бер төс, кыяфәт һ. б. алу, билгеле бер рәвешкә килү. *Әминәнең күңелендә бик куәтле усаллык кузгалган иде: йөзе күгелҗем төскә керде.* Ф. Әмирхан. *Өйалдында Газинурның аяк тавышлары ишетелгәч, Миңнуры яңадан салкын, буйсынмас кыяфәткә керде.* Г. Әпсәләмов.

11. Укыту эшен алып бару, (билгеле бер фән буенча) дәрес бирү. *Рус әдәбияты буенча кергән укытучы Морозов та беренче лекциясен шул фикерләр белән башлады.* Г. Кутуй. *Алгебрадан Муса абый керә.* Д. Аппакова. || Укытылу.— *Җиденчедә химия керә.* Г. Гобәй.

12. Үтү, үткәрелү (электр, су, телефон һ. б.). *Тәрәзәдән кергән телефон чыбыгын тиз арада хәнәҗәр белән кисеп ташлыйм.* Ә. Айдар. *Авылга газ керә, ут керә, су керә.* Г. Ахунов.

13. Акча, байлык һ. б. булу, килү. *Алмалар исәнсау өлгереп, кесәсенә акча керсә, [Галиулланың] хәле бераз рәтләнер иде рәтләнүен.* И. Гази. [*Шәйхизаман:*] *Туры хезмәт итүеңне искә алып, көзгә еллар имин булса, - - - фитыр сәдакалары, корбан тиреләре күп керсә, үзеңә берәр [кыз] - - - алып бирергә булдым.* Т. Гыйззәт.

14. Берәр урынга урнаштырылу, куелу (ашлык, иген һ. б.). *Иген керде ындырларга, Кибән-кибән өелеп.* М. Җәлил.

15. Абстракт исемнәр белән янәшә килеп, нәрсәнең дә булса яклап урнашуын, кабул ителүен белдерә. [*Әминә:*] *Кара әле, туганым, менә хәзер шушындый кофточка модага кергән.* Ф. Әмирхан. *Чабата туку белән берәттән чыбыркы ишү Җаббар абзыйның гадәтенә кереп киткән һөнәре иде.* Ә. Фәйзи.

16. Берәр сыйфатны, хәлне һ. б. атаучы исем белән килгәндә, шул хәл, сыйфат һ. б. ларның барлыкка килүен, шуна ия булуны белдерә. *Җан керү. Хәл керү.* □ *Тегермән буасында, эри башлаган яшел боз өстендә, дәрт кергән ана казлар гаҗылдаша булыр.* И. Гази. *Уйчыннарга ямь кергән.* Ә. Ерикәй. *Әллә каян көч керде; кулның яралы булуы онытылды.* Ә. Айдар.

17. Кая да булса берәр төрле эш, үтенеч белән мөрәҗәгать итү. *Директорга керү. Канцеляриягә керү. Месткомга керү.*

18. Кайбер юнәлеш килешендәге исемнәр янында килеп, шул исем белән белдерелгән берәр нәрсәнең, хәлнең башлануын аңлата. *Бәхәскә керү. Бәйләнешкә керү. Мөнәсәбәткә керү.*

19. *Ярд. ф. функ.* Хәл фигыль янында килеп, нәрсәнең дә булса эченә хәрәкәт итүне белдерә. *Ул арада Сабир абзыйның колхоз амбулаториясендә фельдшер булып эшли торган кызы Мәдинә кайтып керде.* Ә. Еники. *Мин бераз урамнан әйләнеп керәм.* Р. Ишморат.

Керә узу (үтү) — кагылу, кереп чыгу. **Керү взносы** — нинди дә булса оешмага кергәндә түләнә торган взнос.

КЕССОН *и. махс.* Елга яки диңгез төбенә төшеп эшләгәндә кулланыла торган су үткәрмәүче зур камера. *Гыймил эшләгән өченче номерлы кессон. Идел төбендә өч метрлардан да артыграк җиргә керсә дә, таш багана һаман сеңә дә сеңә.* Т. Госман.

Кессон авыруы — кессонда эшләүче кешеләрдә югары атмосфера басымы нәтиҗәсендә барлыкка килә торган авыру.

КЕССОНЧЫ *и. мәхс.* Кессон белән эшләнә торган эшләр белгече; кессонда эшләүче.

КЕСӘ *и.* **1.** Пальто, чалбар, күлмәк һ. б. ларда төрле нәрсәләр салып йөртү өчен эчке яки тышкы якка тегеп куелган кечкенә капчык. *Мин, чалбар кесәмнән шырпы чыгарып, сак кына сыздым.* М. Әмир. *Газинур кулларын чалбар кесәсенә тыкты да - - - фермаларга таба атлады.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Кесәдә йөртерлек, кесәдә йөртергә җайланган. *Сәлим - - - кесә фонаре белән тиз генә шалаш эчен яктыртты.* Г. Гобәй. [*Мансуров*] *сары битле кесә сәгатенә күз төшереп, аны учына йомарлады.* Г. Бәширов.

2. Чемодан, портфель һ. б. ш. кебекләрнең кечкенә махсус бүлеге. *Сумка кесәсе. Чемодан кесәсе.*

3. *күч. сөйл.* Байлык, акча. *Һи, кесәң булсын, тагын табылыр татарның бер кызы!* Н. Исәнбәт. *Егет булгач егет булсын ул — эше белән дә, киемә-салымы белән дә, кесәсе белән дә.* Ф. Хөсни.

◇ **Кесә буш булу** — акча булмау, акча юклык. *Кесә буш булса да, кыяфәт хуш.* И. Рәмиев. **Кесә калынаю** — баю, акча күп җыелу, туплану. *Эше бераз җайланып, кесә калыная төшкәч, [Габделбәр] кассап салдырып җибәрде.* А. Расих. **Кесә карагы** — кесәгә кереп яки вак-төяк урлашып йөрүче кеше. **Кесә сай, такыр (булу)** — акча аз булу, акчасызлык. *Кесә сай, кул кыска.* Мәкаль. [*Бибкәй:*] *Кесәләре такыр булса да, киемнәре бик мулдан.* М. Фәйзи. **Кесә такыраю (саегу, сайга калу)** — акча бетү, бөлү. *Кесәң такырайса, күршең сукыраяр.* Мәкаль. *Кызларын бирәләр байга, туйлары тартыла ике айга, Кесәләре каладыр сайга.* Ш. Мөхәммәдев. **Кесә талаучы** — 1) *к.* кесә карагы; 2) төрле юллар белән башкаларның малын, акчасын үзләштерүче, кеше хисабына яшәүче. *Монда бар залим тараф, күзгә карап алдаучылар, Башкаларның*

күзләрен бәйләп, кесә талаучылар. М. Гафури. **Кесәгә дә йокмау** — бик аз булу (акча турында). *Алманың акчасы кесәгә дә йокмады: ертык-тишек урын күп булгач, акчаны күрми дә калдылар.* И. Гази. **Кесәгә кереп тормау** (сүз өчен) — сүзгә аптырап калмый торган кеше турында әйтелә. **Кесәгә кулны тыгып** — ваемсыз, бернинди хәсрәтсез һәм эшсез-шөгыльсез (йөрү, яшәү). **Кесәгә керү** — кеше кесәсеннән акча һ. б. алу, урлау. *Кешенең кесәсенә кермәдем.* Г. Ибраһимов. **Кесәгә сугу** — зур чыгым тотылу, акча ягыннан авырлык килү турында. **Кесәдә калу** — экономия булу, экономия ясау. *Бакча җимеше булганда, акча кесәдә кала.* Ә. Еники. **Кесәдә җил уйнау** — акча булмау. **Кесәдән йодрык күрсәтү** — турыдан-туры әйтергә, эшләргә батырлык, кыюлык җитмәү. *— Акча килгән чакта кесәдән йодрык күрсәтү ансат булса да, Малик карунны үпкәләтү ярамый.* И. Гази. **Кесәне саву** — әкренләп берәр кешенең акчасын, байлыгын алып бетерү. *[Мәликә картына:] Кесәңне саварга тели торгандыр шул [киленең].* А. Шамов. **Кесәне тишмәс** — кирәге чыгар, файдасы тияр мәгънәсендә (кулга керергә торган байлыктан баш тартмаска өндәгәндә кулланыла); синонимы: эчне тишмәс. *Акча күбрәк төшсә, кесәмне тишәр дип куркасыңмыни?* И. Гази. **Кесәсе калын (юан)** — бай, акчалы кеше турында. *„Кесәсе юанрак яшь байларны син безгә алып килергә дәлаләт кылыш“,— дип, мине буш ашатып-эчертәләр.* Ш. Мөхәммәдев. **(Үз) кесәсенә салу** — нәрсәне дә булса үзләштерү. **(Үз) кесәсен кайгырту** — үз файдасын гына карау, үзе өчен генә кайгырту. **(Үз) кесәсеннән (кесәңнән) чыгару** — үзең түләү. *Иң киме --- ун мең сумнар акча кирәк булыр. Моның яртысын Сарсымбай үз кесәсеннән чыгарса, калганын башкалар күтәрер.* Г. Ибраһимов.

КЕСӘБИКӘ *и. иск.* Кыска җиңле, мамык белән сырылган, кырыйларына мех тотылган хатын-кыз киеме. *Янә хатыннарның кесәбикә дигәң киемнәре дә бар.* К. Насыйри. *Өстә кесәбикә, бөтен җире бизәк, Күлмәк юк, башкасы нигә кирәк?* Әйтем.

КЕСӘЛ *и.* 1. Җиләк-жимеш согына, сөткә һ. б. ларга крахмал кушып хәзерләнгән койка сыман ашамлык. *[Фәрхи карчык] токмачтан соң бәрәңге белән куырылган ит, актыкта компот яисә кесәл хәзерли иде.* Ш. Камал. || Ачыга изелгән солы оныннан сөзеп пешерелгән боламык (сөт белән ашыйлар). *Солы кесәле.*

2. *күч.* Нинди дә булса үзле, ярым сыек масса. *Колчеданнар кесәл булган җиргә Сез гомердә дә, бәлки, кермәссез. Ә менә шунда миңа таныш кеше Гомер буе эшли күлмәксез.* Ш. Маннур.

КЕСӘЛЛӘНДЕРҮ *ф.* Кесәл хәленә китерү.

КЕСӘЧЕ *и.* Кесә карагы. *Кырмыска күче төсле бертуктаусыз кайнап тора торган базарлары, --- һәм атаклы кесәчеләре белән Казан кечкенә Фәйзулланы шаулап каршы алды.* Ф. Хөсни.

КЕТА *и.* Сөләйман балыклар семьялыгыннан ашау өчен тотыла торган диңгез балыгы. *Симка үзе курҗынны актарып өстәлгә --- берничә бәйләм колбаса, зур бер кета балыгы ташлады.* И. Салахов. || *с. мәгъ. Кета икрасы.*

КЕТГУТ *и. махс.* Сарык, кәҗә эчәкләреннән ясала торган жеп; хирургиядә эчке җөйләрне теккәндә кулланыла. *Операция ясалган урынны тегү өчен иң кадерле нәрсәләрнең берсе — кетгут.* С. Шакир. || *с. мәгъ.* Кетгут эшләп чыгара торган. *Әти белән бертуган ике апам кетгут заводында эшлиләр иде.* Соц. Тат.

КЕТЕР *аваз иярг.* Кайбер әйберләрне чәйнәгәндә, кимергәндә ишетелгән жиңелчә шытырдау тавышларын белдерә. *[Куян] кетер-кетер итеп агач кайрысы кимергән.* А. Алиш.

КЕТЕРДӘВЕК *с.* Кетердәп торган. *[Нәфисәнең] абыйларындагы кебек тәмле сөзмә, аның җиңгәсе пешергән кебек кетердәвек коймак — бүтән беркемдә дә булмый иде.* Г. Бәширов.

КЕТЕРДӘВЕКЛЕ *с.* Кетерди торган.

КЕТЕРДӘТҮ *ф.* Кетер-кетер китерү. *Яшь бәрәннәр ак тешләре белән кетердәтеп печән чәйнәде.* Ш. Маннур. *Берничә минут буена [Ифрат белән Баһавиның] кабаланып кәбестә кетердәтүләре --- ишетелеп торды.* А. Расих.

КЕТЕРДӘҮ *ф.* 1. Кетер тавышларын хәтерләтеп жиңелчә шытырдау; зәгыйфь шытырдау. *Бәлешне ашаганда мактап бетерә алмадылар, --- төбе, камыры кетердәп тора, дигәнсең, зур таба төбендә тик оятлык кына калдырдылар.* Г. Ибраһимов.

2. *рәв. мәгъ. сөйл.* **кетердәп.** *к.* кеткелдәү: кеткелдәп. *Нәсимә кетердәп көлеп җибәрде.* Ш. Камал.

КЕТИ: кети-кети итү (уйнау) — кытыклау, кытыклашу. *Яшь егет! Килче икәү уйныйк бераз кетикети.* Г. Тукай.

КЕТКЕЛДЕК *с.* Һаман кеткелдәп тора торган. *Бигрәк кеткелдек кыз.*

КЕТКЕЛДӘҮ *ф.* Йомшак кына өзек-өзек тавыш чыгарып көлү. *Вәли абзый йөзем суын эчкәннән соң, шаярып: — Ах, иблис хатын, моның эченә син колмак салгансың ахры,— дип кеткелдәде.* Ә. Фәйзи. || *рәв. мәгъ.* **кеткелдәп.** Йомшак кына өзек-өзек тавыш чыгарып. *Мыеклы һич көтелмәгәндә, мыегын бөтерә төшеп, кеткелдәп көлеп куйды.* А. Расих.

КЕТ-КЕТ: кет-кет итү (көлү) — *к.* кеткелдәү. *Кеткет итеп Гөлкәй көлеп куйды, „Ай-һай телең ачы, Харис!“ — дип.* М. Җәлил.

КЕТӘК *и.* Йорт кош-кортлары асрау өчен махсус корылма. *Тавык кетәгендәге әтәч иренеп кенә кычкырып куйды.* Г. Гобәй. || *күч.* Кечкенә, кысан бүлмә турында. *Фәтхине --- караңгы кетәк өзелеп сөйгән Мәдинәсеннән аерды.* Ш. Камал.

КЕТӘКЛЕК *и. диал. к.* кетәк. *Кетәклек башында, өрлек астында, салам куышында иде чуар тавыкның оясы.* А. Алиш.

КЕФАЛЬ *и. зоол.* Юка, озынча гәүдәле, зур башлы диңгез балыгы. *Кара диңгездәге кефаль бүлыгын Каспий диңгезенә күчерделәр, һәм биредә ул бик нык үрчеп, промысел балыгына әйләнде.* Зоология.

КЕФИР *и.* Сөткә ачыткыч бактерияләр салып оеттырган туклыклы куе эчемлек. *[Идрис] --- кафеда бифштекс ашап, бер стакан кефир белән хушланган, --- өченче каттагы бүлмәсенә күтәрелде.* А. Гыйләҗев.

КЕЧЕ *с.* 1. Күләме белән зур булмаган, кечкенә; *киресе:* зур. *Ярым ачык кече капкадан бәләкәй әт йөгереп чыкты да кинәт туктады.* Ш. Камал.

2. Кем белән дә булса чагыштырганда ел исәбе буенча яшьрәк. *[Мәликә] җиңгинең кече улы Әхмәт кичә үк яланаяк урамга чыгып керде.* Һ. Такташ. | *и. мәгъ. Олы, кече берләшеп, илгә хезмәт итәрбез, Берләшеп хезмәт итсәк, рәхәт гомер итәрбез.* Г. Камал. — *Сөйлә әле, туган, олы малай ни эшләп йөри ие, уртанчысы, кечесе, кызчык, анасы ни эшләп йөри ие? — дип тезеп китте Гайнулла.* А. Әхмәт.

3. Дәрәҗәсе, хезмәттәге урыны, вазифасы буенча өлкәнрәкләрдән түбән булган. *Кече редактор.* | Званиеләрнең, вазифаларның түбәнрәк икәнен белдергән рәсми атамаларда. *Кече сержант. Кече гыйльми сотрудник.* □ *Кече лейтенант Григорян сафка соңгы тапкыр күз йөртте дә команда бирде.* Г. Әпсәләмов.

4. Кайбер атамалар һәм ялгызлык исемнәре составында нәрсәнең дә булса кечерәк күләмдә икәнлеген

белдерү өчен килә. *Кече театр. Кече совет энциклопедиясе.*

Кече атна — *к.* атна кич. [*Укытучы малайларга*] *кече атна көннәрдә шул китапларны укып торырга бирә иде.* Г. Бакиров. **Кече тел** *анат.*— йомшак аңкауның арткы өлешендә йоткылыкны ачу-ябу өчен хезмәт итә торган әгъза. **Кече як** — өйнең кечкенә ягы, кухня. *Безне, хәзерге киленнәрне, алай кече якка гына яшереп булмый инде.* Г. Бәширов. **Кече яшьтәге (балалар)** — мәктәпкәчә яшьтәге. **Кече яшьтән** — бик кечкенәдән, бала чактан. *Гриша кече яшьтән патша гаскәренең драгун полкында тәрбияләнеп үскән.* Ш. Усманов.

◇ **Кече күңелле** — башкаларга һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торучы, ихтирам, олылау, хөрмәт күрсәтүче кеше турында. [*Дускаевның хатыны*] *бик ачык йөзле, кече күңелле, берүнең дә йомышын кире кайтармый.* Ә. Еники. **Кече телгә дә җитмәү (тимәү, йокмау)** — бик әз булу, җитми калу, туярлык булмау (ашамлык-эчемлекләр турында). *Биш кечкенә балык олы телдән кече телгә җитмәде.* Ә. Фәйзи. **Кече хатын** — мөселман динендәге күп хатын белән торучы ирләрнең иң соңгы хатыны. *Салмас өчен читкә күзне, Алып куйдым кече хатын.* Г. Камал.

КЕЧЕК *с. иск. к.* кечкенә. *Ялгыз кечек өй куе караңгылык эчендә юк булды.* Г. Ибраһимов.

КЕЧЕЛЕК *и.* 1. Дәрәҗә, хезмәт урыны, вазифа ягыннан түбәнлек. *Кечелектән олы булган кеше һәркем каршында да мактаулы.* Ф. Бурнаш.

2. Түбәнчелеклелек, түбәнчелекле булу, ихтирамлылык. *Үзенә иң якын нәрсәләрнең, иң кадерле истәлекләрнең һәммәсе белән дә берьюлы саубуллашкан кебек, кечелек белән башын иеп:— Хушыгыз!— диде* [*Нәфисә*]. Г. Бәширов.

КЕЧЕЛЕКЛЕ *с.* Түбәнчелекле, юл куючан, ихтирамлы. *Хәят --- кечкенәдән үк --- кечелекле булырга өйрәтелгән иде.* Ф. Әмирхан. [*Мәгъри:*] *— Шулай, шулай, бик һәйбәт, бик кечелекле кеше* [*бикә*]. Г. Камал.

КЕЧЕЛӘНҮ *ф.* 1. Кечелекле булу, кечелек күрсәтү. *Ана алдында кечеләнү.*

2. *к.* кечерәю 1.

КЕЧЕРӘЙТКЕЧ *с.* Берәр нәрсәнең сурәтен кечерәйтеп күрсәтә торган. *Кечерәйткеч пыяла.*

КЕЧЕРӘЙТҮ *ф.* 1. Күләм ягыннан киметү, кечкенәгә әйләндерү. *Галәү бабай, болай да кечкенә күзләрен кечерәйтә төшеп, озын буйлыга карап торды.* Г. Гобәй. || Азайту, аз калдыру, киметү.

2. Әкренәйтү, көчен киметү. *Газны кечерәйтү. Утны кечерәйтү.*

3. *күч.* Киметү, төшерү (нәрсәнең дә булса әһәмиятен, бәясен һ. б.). *Кыю кызлар темасының бу [„Кыю кызлар"да] пьесада бер сәбәп кенә булып калуы әсәрнең эчтәлеген һәм кыйммәтен кечерәйтә.* М. Җәлил.

КЕЧЕРӘЮ *ф.* 1. Күләм ягыннан кимү, кечкенәгә әйләнү; *киресе:* зураю. *Озак вакытлар читтә йөреп, зур-зур шәһәрләрдә эшләп кайткан кешегә үз авылы һәрвакыт кечерәйгән, искергән --- күк тоела.* Г. Әпсәләмов. || Сан ягыннан азаю, аз калу, кимү. *Ул юк арада взвод шактый ук кечерәеп калган.* Г. Бәширов.

2. Әкренәю, көче кимү.

3. *күч.* Кимү, төшү (нәрсәнең дә булса әһәмияте, бәясе һ. б.). *„Беренче театр" комедиясендәге башка образлар да матур эшләнгәннәр. Тик аларга караганда күп көчле эшләнгән Хәмзә бай тибы белән томаланып кына алар беркадәр кечерәя төшкәннәр.* М. Гали.

КЕЧКЕНТӘЙ *с. диал.* Зур булмаган, бик кечкенә, нәни генә. *Самовар капкачын өстәл янына алып килде дә, ду күчеп утырган кечкентәй самоварны каплый-каплый:— Без хәзер генә аналы-кызлы эчкән идек,— диде* [*Сәгыйдә карчык*]. Ш. Камал.

КЕЧКЕНӘ *с.* 1. Зурлыгы, күләме, үлчәме һ. б. зур булмаган. *Бу кечкенә хат миңа зур көч биргәндәй булды.* Ә. Айдар. *Конверт эченнән урталайга бөкләнгән кечкенә саргылт кәгазь чыкты.* Ә. Еники. || Сан ягыннан күп булмаган, аз санлы, аз. *Кома[ндир] янында кечкенә генә төркем оешты.* А. Ша[мов]. || Кыска, тәбәнәк (кешенең буе, гәүдәсе турында). *Командир --- каршында төз басып торган кечкенә гәүдәле Бикбулатовны күңеленнән үзенең таза егетләре белән чагыштырып алды.* А. Әхмәт.

2. Артык көчле булмаган (тавыш һ. б.). *Лиза үзенең кечкенә, ләкин мәхәббәтле сопраносы белән бер романсның башын җырлап җибәрде.* Ф. Әмирхан. || Җитди булмаган, мөһим булмаган, артык әһәмияткә ия булмаган. *Дсәрдәге баш рольләрдән башлап, иң кечкенә рольләргә кадәр бөтен уен --- җентекләп эшләнгән.* М. Җәлил. || Артык зыянлы, куркынычлы булмаган. [*Насыйров:*] *Кечкенә авария белән котылдык.* Р. Ишморат.

3. Җәмгыятьтә һәм хезмәттә зур урын тотмаган. *Ә мин үземне бер бик кечкенә кеше итеп сиздем аңардан.* Һ. Такташ. *Сәгъди бабай йомшак табигатьле. Кеше сүзенә ияручан кечкенә бер сәүдәгәр.* Ш. Камал.

4. Яшь, сабый. *Бик кечкенә идем, ә шулай да Барын, барын күңел саклаган.* Ш. Маннур. *Кызык күреп кенә тотынган кечкенә балалар таралышып беттеләр.* Г. Гобәй. | *и. мәгъ. Йоклый алмый кечкенәсе: „Дткәй кайда минем?" — дип.* Ә. Ерикәй.

5. *и. мәгъ. күч. сөйл.* 250 гр. сыешлы шешәгә салынган аракы турында. [*Шмит*] *кибет ачылу белән, --- бер „кечкенә"не алды һәм аны теге чыбык очы кардәшенә кереп берүзе эчте.* А. Расих.

КЕЧКЕНӘДӘН *рәв.* Яшьтән, балачактан. *Михаил да, Лиза шикелле үк, Хәятнең кечкенәдән бергә уйнап үскән иптәше иде.* Ф. Әмирхан.

КЕЧКЕНӘЛЕК *и.* Кечкенә булу (күләме, әһәмияте, зурлыгы ягыннан). [*Газинур:*] *Безнең тәрәзәбезнең кечкенәлегенә, гөләп чәчәгем, исең китмәсен, ул зур дөньяга карый.* Г. Әпсәләмов.

КЕЧКЕНӘЛӘНҮ *ф.* Кечерәю. *Туры ат бик кечкенәләнде.* М. Гафури.

КЕЧТЕК *с. диал. к.* кечкенә. [*Кендекнең*] *нечкә очына кечтек тишек аркылы кәкре кадак үткәрелгән.* Г. Ибраһимов.

КЕЧТЕКИ *с. диал. к.* кечкенә. *Шәмси --- Нәсимәсенә кечтеки генә хат язып ташлады.* Г. Бәширов.

КЕШ *и. зоол.* 1. Көрән төстәге кыйммәтле мех бирә торган зур булмаган ерткыч җәнлек; *русчасы:* соболь. [*Эвенк*] *кыйммәтле кеш тиреләрен елкылдатып, --- кайтып керә.* Каз. утл.

2. Шул җәнлекнең тиресе. || *с. мәгъ.* Шул мехтан тегелгән, эшләнгән. *Кеш бүрек. Кеш яка.*

КЕШЕ *и.* 1. Фикерләү, сөйләшү, корал җитештерү һәм аннан хезмәттә файдалана алу сәләтенә ия булган зат, җан иясе, шәхес. *Кеше үзенең бәхетен хезмәт чишмәсеннән таба.* Г. Әпсәләмов. || *тарт. форм.* Нинди дә булса уртак сыйфатларга ия булган, берәр төрле средада, оешмада һ. б. ш. ларда исәпләнгән зат, шәхес. *Фән кешесе. Шәһәр кешесе. Партия кешесе.* □ [*Җамали:*] *Дөресен әйткәндә, газета кешесенә керергә ярамый торган җир юк.* А. Әхмәт. *Галимне сәнгать кешеләре алыштырды.* А. Гыйләҗев. || Кардәшлек мөнәсәбәтләре, женес һәм яшь бүленешләре буенча билгеле бер класска кергәнлекне белдерә. *Кыз кеше. Карчык кеше. Егет кеше.* □ *Бала, ---ят кешене күргәч, берникадәр аптырап торды.* Г. Минский. *Ир кеше тавышын ишеткәч тә, тиз генә кит-*

төм. М. Фәйзи. || Югары мораль һәм рухи үзлекләр гәүдәләнеше буларак шәхес. *Мине дә партия эшенә яраклы кеше итеп беренче чиратта Шаһгәрәй абзый тәрбияләде.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Санау берәмлеге мәгънәсендә кулланыла. *Көндезге аштан соң корабтагы йөз дә унике кеше барысы да бергә җыйналдылар, бер гаиләдәй булдылар.* А. Алиш. *Төркем янына Ислам соңгы кеше булып килде.* Н. Фәттах.

3. Кем дә булса, берәрсе; беркем. *Я кеше кереп бүлдерә, я берәрсенә алып китәләр.* Т. Гыйззәт. *Кеше булмаган көнне Хәгрниса анасы белән бергәләп --- жеп эюли, оек бәйли.* К. Нәҗми. [*Гали*] *--- кешесез калган ана белән кызга яклаучы вә гаилә башлыгы булуны үзенә зур бәхет саный.* Ш. Камал.

4. Икенче берәү, чит, ят адәм (билгесез затны белдерү өчен кулланыла). [*Айдар:*] *Маңгаем белән таш стеналы ватармын, ә Вәсиләне кешегә бирмәм.* Ф. Хөсни. *Иртәдән кичкә хәтле кешеләргә тегү тегеп утырган --- Газизә янында әлеге кирәк кешене һич очрата алмый* [*Хөсни апа*]. Ш. Камал. [*Хәлимә*] *кеше алдында хәтер калдыргыч саксызлык күрсәтте.* М. Хәсәнов.

5. *сөйл. күч.* Сөйгән яр, ир буласы яки дус егет. *Чибәрлеген сөйләп тормыйм: Гашыйк булырлык һәркем. „Сүз күешкан кешем бар" дип, Кырт кистем сүзне ләкин.* З. Мансур.

◇ **Кеше арасына керү** — 1) җәмгыятьтә, тормышта үз урынынны булдыру. [*Мөршидә Гөлчирәгә:*] *Кеше арасына кергәч, апаң артык булгандыр шул.* Т. Гыйззәт; 2) дусларны читләштереп, араларын бозып, берсен үз ягына тарту. **Кеше аягы басмаган, тимәгән (урын, жир)** — кеше булмаган, кеше йөрми торган. [*Карчык:*] *син, бәбкәм, кеше аягы басмаган җиргә ничек килеп чыктың?* А. Әхмәт. *Ул аланның тирәягы Булган һич кеше аягы Тимәгән сазлык.* Ә. Исхак. **Кеше аягы тыну** — тулы тынлык урнашу, кешеләр йөрүдән туктау (төн турында). *Урамнарда кеше аягы тынган.* Г. Бәширов. **Кеше булу** — 1) югары мораль һәм рухи үзлекләргә ия булу. *Кеше булган кешедә мең кешенең эше бар, кеше булмаган кешедә кешенең ни эше бар!* Мәкаль; 2) тормышка яраклы булу, тормыш итәрлек кеше булу. *Балам, тырыш: тырышуың аркасында кеше булсаң, милләтеңә күрсәтерсең шәят бер эш.* М. Гафури; 3) каты авырудан терелү, өметсез булып саналган авырудан терелү, аякка басу. **Кеше исәбенә яшәү** — кемнең дә булса акчасыннан яки әйберләреннән файдаланып, соры корт булып яшәү. **Кеше итү** — 1) кемгә дә булса тормышта, җәмгыятьтә үзенә урын табарга ярдәм итү, тәрбияләү. *Рәхмәт әйтәм туган жиремә мин, Ул үстергән мине, кеше иткән.* Ә. Ерикәй. *Эш кенә кешене кеше итә, туры юлга күндерә.* М. Гафури; 2) каты авырудан терелтү, аякка бастыру. **Кеше итеп карау** — санлау, исәпләшү, хөрмәт итү. **Кеше күлына калу** — 1) авыру, гарип булу яки картлык аркасында башкалар ярдәменә мохтаж булу; 2) кемгә дә булса буйсынып яши башлау, үз иркен югалту. [*Фәхерниса:*] *Әй минем әүвәлдә рәхәтләнеп, шатланып гомер сөргән, соңыннан --- минем кеше күлына калуыма сәбәп булган йорт! Хуш, сау бул!* Г. Камал. **Кеше көлкесе итү (ясау)** — мәсхәрә итү, хурлыкка төшерү. [*Әпипә Солтанга:*] *Кеше көлкесе итеп калдырма!* Г. Бәширов.— *Мин аларны шундый кеше көлкесе ясыйм, ялчы Байтирәкне балаларының балалары да оныта алмаслар.* Т. Гыйззәт. **Кеше рәтенә керү** — 1) үсеп, мөстәкыйль яши башлау. *Җитәр инде, вакыт миңа Кеше рәтенә керергә!* М. Җәлил; 2) *к.* кеше арасына керү; 3) авырудан терелү. **Кеше сүзе** — гайбәт. *Кеше сүзе — кеше үтерә.* Мәкаль. **Кеше өстендә (яшәү, тору)** — чит кеше өендә (яшәү, тору). *Язмышың, тормышың юл белән бәйле булгач, төрле хәлләр була. Кеше өстендә дә торырга туры килгәли.* М. Хәсәнов. **Кешегә калу** — кемнең дә булса ярдәменә мохтаж булу, мөстәкыйль яши алмау. *Кешегә калган көн — таң атмаган төн.* Мәкаль.

КЕШЕ-КАРА *и. сөйл.* Кем дә булса, кемдер, берәрсе. *Вәлиуллин, кеше-кара ишетмәсен дигән төсле, кабинет ишегән тартыбрак япты.* К. Нәҗми.

КЕШЕЛЕК *и.* **1.** Кешеләр, кешеләр җәмгыяте. *Өметсезлек белән шәхес тә, кешелек тә яши алмый.* А. Гыйләҗев. *Туган калам! Аңлы көрәш юлын Бөек Ленин синдә башлаган, Кешелекнең җиңүенә илткән Тәүге адымын синдә ясаган.* Ә. Исхак.

2. Кешегә хас сыйфатлар. *Туңып, күшеген, тәмам кешелеген җуйган Хәйруш көч-хәл белән станциягә килеп җитте.* М. Хәсәнов.

3. Кеше булу, кешелеклелек, шәфкатьлелек. *Көчлеләген белән горурланма, Кешелегең белән горурлан!* М. Җәлил. *Эш кешенең кешелеген дә, дәрәҗәсен дә арттыра.* М. Гафури.

4. Кеше арасына чыкканда гына, яхшыга, кадергә генә кия торган кием турында. *Өйлеге юк кешеләген кияр, кешелеге юк кешенекен кияр.* Мәкаль. [*Гөлшаһидә*], *бераз тынычлангач, кешелеккә кия торган күлмәген чемоданнан чыгарды.* Г. Әпсәләмов.

5. *с. мәгъ.* Күпмедер кешегә исәпләнгән, ...гә җитәрлек, ...дән торган, ... генә сыярлык. *Ачык көн, якты кояш астында утызар-кырыгышар кешелек табыннар ясалды.* Г. Ибраһимов. *Бер генә кешелек тар сукмак безне бер-беребезгә якын ук китереп кысты.* Ф. Әмирхан.

◇ **Кешелектән чыгу** — 1) гарипләнү, сәламәтлекне югалту. [*Сәрби:*] — *Менә бу бабай булмаса, алар хәзер үк мине кыйнап кешелектән чыгарган булырлар иде.* Ф. Бурнаш; 2) бозылу, бозык табигатьле кешегә әйләнү. [*Шәрәф*] *читкә китеп кешелектән чыкты.* М. Фәйзи.

КЕШЕЛЕКЛЕ *с.* Шәфкатьле, мәрхәмәтле, мөлаем, кешегә ярдәм итүчән. [*Хөсәеннең*] *ягымлы сүзеннән һәм кешелекле йөзеннән аның чынлап та акыллы, укымышлы егет икәнен сизә идек.* Ә. Фәйзи. [*Мөршидә Хәмиткә:*] — *Юк, дустым, мин сине кешелекле һәм батыр йөрәген өчен сөйдем.* Р. Ишморат.

КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК *и.* Кешелекле булу сыйфаты.

КЕШЕЛЕКСЕЗ *с.* Шәфкатьсез, мәрхәмәтсез, тупас.

КЕШЕЛЕКСЕЗЛЕК *и.* Кешелексез булу сыйфаты. [*Саматов*] *үзенең бу тикле гамьсезлеге, кешелексезлеге өчен шашынырдай булып көенә.* Г. Минский.

КЕШЕЧӘ, КЕШЕЛӘРЧӘ *рәв.* Кешеләргә хас булганча; кешеләр кебек, кешеләрдәй. *Кешеләрчә яшәү хисе көчле Безнең бөек совет халкында.* Ә. Ерикәй. [*Шәриф*] *үзе бизгәк тоткан кешеләрчә дер-дер калтырый.* М. Гафури. *Кешечә, менә шундый-шундый хәлләр дип, тәртибе белән бервакытта да сөйләп бирми* [*Мансур*]. Г. Әпсәләмов. *Катышкан кешең бай булгач, сиңа да азрак кешечә кыланмый туры килми.* М. Фәйзи.

КЕШЕ-МАЗАР *и. к.* кеше-кара. *Әле Илсөяр, әле Бикмүш бабай кеше-мазар килеп чыкса дип, әйләнәтирәне күзәтеп килделәр.* Г. Гобәй.

КЕШЕ-ФӘЛӘН *и. к.* кеше-кара. [*Чаршау*] *кирәкмәгәндә күтәрелеп тора, кеше-фәлән килсә, кирәге чыкса, миң буеннан стенагача тартып куясың.* Г. Ибраһимов.

КЕШЛЕК: кешлеккә кия торган — *к.* кешелек (4 мәгъ.). [*Фәйрүзә*] *сандыкны туздырып киемнәрен алды, кешлеккә кия торган ике күлмәгенең бүген кайсысын кияргә белмичә --- озак кына тапталып торды.* Г. Ахунов.

КЕШНӘУ *ф.* 1. Тавыш, аваз чыгару, кычкыру (ат турында). *Дымсу һаваны чыңгырдатып, кайдадыр яшь тай кешнәп җибәрә.* Г. Бәширов. [*Ат*] *шатланып кешни-кешни, өзек нуктасын өстерәп, кавалеристлар артыннан куып җитте.* А. Шамов.

2. *күч. сөйл.* Кычкырып, тотнаксыз көлү.— *Нәрсә айгыр кебек кешнисең?* Г. Әпсәләмов.

КЕШТЕРТ *аваз ияр.* Җиңелчә кыштырдау тавышын белдерә. [*Ат*] *кештерт-кештерт китереп утлыктан печән ашап тора.* Н. Фәттах.

КЕШТӘК *и.* Өске һәм эчке киемнәрнең тиешле урыннарын кинәйтү һ. б. ш. максатлар өчен тегелеп куела торган өчпочмак яки ромб формасындагы материя кисәге. *Кештәкнең* [*бер*] *ноктасы җиң очы юнәлешендә урнашырга тиеш.* Йорт эшләре.

КЕШӘН *и.* Атның алгы ике аягын тышаулап, бер очын арткы аягына бәйләп куелган озын бау. *Без дә кеше булырбыз, Атка кешән салырбыз.* Әйтем.

КЕШӘНЛЕ *с.* Кешәнләгән, кешәнләп җибәрелгән. *Кешәнле ат кирәгеннән ары йөрмәс.* Мәкаль.

КЕШӘНЛӘУ *ф.* Кешән белән бәйләү. *Йөремтәк атны кешәнлиләр.* Әйтем. *Кеше баласын кешәнләсәң дә тормас.* Мәкаль.

КИ *терк.* Иярченле кушма җөмләдә ачыклау мөнәсәбәтен белдерә. *Дөньяда күп кешеләр бар ки, үткен вә гакыллы кешеләрдән куркып, үз тирәләрендә күбрәк ахмакларны йөртәләр.* Г. Тукай.

КИБАР *и. иск. кит.* Горурлык, масаю. [*Ай*] *артык матур вә хыялый төстә нурлы, ләкин бу нурда вә бу югарылыкта мөлаямәт вә иркәлектән бигрәк кибар катыш салкынлык бардыр шикелле тоела.* Г. Ибраһимов.

КИБАРАНӘ *рәв. иск. кит.* Эреләнеп, тәкәбберләнеп, һавалы; горур, тәкәббер. *Хәмдия бер креслога кибаранә генә утырган.* М. Фәйзи. *Кибаранә күтәреп баш, безнең таш-тау Селкенми дә, кузгалмый да тора сап-сау.* Г. Тукай.

КИБАРИ *с. иск. кит.* Олы сыман, горур. *Түрә --- озын буйлы, калынрак гәүдәле, ак сакаллы, мәһабәт вә кибари кыяфәтле.* Г. Ибраһимов.

КИБАРЛЫК *и. иск. кит.* Эрелек, тәкәбберлек, олы сыманлык. *Бай да бик яхшы беләдер монда йомышы барлыгын: — „Ни кирәк?“ — дими, сорамый, ташламый кибарлыгын.* М. Гафури.

КИБЕГҮ *ф.* 1. Сусау, эчәсе килү. *Уттай эссе көнне, сусыз калып, Кибеккәнең, белмим, бардырмы?* З. Мансур. *Син кибексәң, суларга, Салкын чишмә булырмын.* Ш. Маннур.

2. Бик ныклы ябыгу. [*Тәзкирә:*] — *Алай ашамый йөрсәң, бик тиз кибегерсең монда, җанкисәгем.* Н. Фәттах.

3. *диал.* Ныклы кибү, коргаксу.

КИБЕКТЕРҮ *ф. сөйл.* Төрле рухи газаплар, җәберләүләр белән йончытып ябыктыру (кешегә карата). *Ачуым — ачу, кибектерәм әле мин аны, дип әйтеп әйтәдер ди* [*Нәфисә*]. Г. Бәширов.

КИБЕНҮ *ф. сөйл.* Чыланган өс-башны киптерү.

КИБЕР *и. иск. кит.* Горурлык, тәкәбберлек, эрелек. *Бу нинди игътибарсызлык! Матурлыктан туган бер киберме бу?* Ф. Әмирхан.

КИБЕРЛЕ *с. иск. кит.* Горур, эре, тәкәббер. *Җәлил --- күкрәген, бөтен торышын киберле бер кыяфәткә китереп турылатты.* Г. Ибраһимов.

КИБЕРНЕ'ТИК I *и.* Кибернетика белән шөгыльләнүче.

КИБЕРНЕ'ТИК II *с.* Кибернетикага караган, шуна бәйләнешле. *Күзләр кибернетик машинага — кеше үзенә ярдәмче итеп төзегән акыллы автоматка текәлде.* А. Тимергалин.

КИБЕРНЕ'ТИКА *и. махс.* Төрле процессларның (механик, электрик, электрон, физиологик һ. б.) автомат контрольлеген һәм үзрегуляциясен, аларның модельләштерелүен өйрәнү теориясе. *Кибернетика шундый үсешкә ирешкән ки, автомат идарә итү машиналары, пространствоның куркынычсыз өлкәләрен сайлап, теләсә кайсы планетага очу проблемаларын чишеп бирәләр.* Соц. Тат.

КИБЕТ *и.* Товарларны ваклап сату өчен булган сәүдә предприятиесе һәм шулай сату өчен махсус яраклаштырылган бина. *Туры якалы яшькелт күлмәкне Газиз, эшкә кияргә дип, район кибетеннән алып кайткан иде.* Г. Бәширов.

КИБЕТЧЕ *и.* 1. *сөйл.* Сатучы, кибеттә эшләүче. *Кибетче товарларын рәтли, тузанын каккалый.* А. Әхмәт.

2. *иск.* Кибет тотучы (бай); шул кибеттә сату итүче. *Кибетче Зариф малае бөтен яктан кәгъф булыр инде ул.* Ф. Хөсни.

КИБЕТЧЕЛЕК *и.* Кибетче вазифасы, кибетче хезмәте. [*Шөһбаг:*] — *Соңыннан эти мине --- Җамали абзыйга кибетчелеккә бирде.* Г. Камал.

КИБӘК *и.* 1. Башаклы игеннәрне һәм башка кайбер культураларны сукканда, чистартканда барлыкка килә торган калдыклар. *Машинаның астына коелган башаклар, кибәкләр дә шунда ук чыгарылып аерым өемнәргә өелә баралар.* М. Гали. *Орлык кибәксез булмый.* Әйтем.

2. *диал. к.* **кавык.**

3. *эвф. к.* кандала. *Йосыф муеныннан кибәк тот-*[*ты*]. Г. Коләхметов.

◇ **Кибәк баш(лы)** — ангыра, мингерәү (кеше турында). *Кибән чалма кибәк башта, Ишан булган имеш, хайван.* Г. Тукай. *Кибәк башлы „Җәләл хан“ булганчы, ертык бәтинкәле писып булу әлбәттә артыграк! — дип өстәп җибәрде Габдулла.* Ә. Фәйзи. **Кибәк очыру** — ялганлау, ялган кушып сөйләү.

КИБӘКЛӘНҮ *ф.* Кибәклегә әйләнү, кибәк белән буталу, аралашу.

КИБӘН *и.* Печән, салам яки сугылмаган ашлыктан ачык һавада саклау өчен зур итеп салынган чүмәлә. *Печәннәр җыелып бетеп, кибән куелды.* М. Гафури. *Кырыйлары читән белән тотылган бу ындырларда кар белән капланган бер-ике арыш кибәне белән берничә әвеннән башка нәрсә күренмәде.* М. Гали.

◇ **Кибән башы** — кыерчык (ипидә). *Әтинең түгәрәк икмәкне башлап кискәндә, „кибән башы иң элек менә малай кешегә!“ дип, --- миңа кисеп куйганлыгын хәтерлим.* Ф. Хөсни. *Түгәрәк ипинең кибән башыннан соң калын гына җиде-сигез телем теленгән иде.* А. Гыйләҗев.

КИБӘНЛӘҮ *ф.* Кибәнгә өю, кибән кую. *Кайбер колхозларда печәнне тозлап кибәнлиләр икән.* Ә. Еники.

КИБҮ *ф.* 1. Дымы бетеп корыга әйләнү (юеш, дымлы әйберләр турында). *Яңгырдан соң* [*Газинурның*] *кепкасы әле рәтләп кибеп тә җитмәгән иде.* Г. Әпсәләмов. || Тиешле юешлеге, дымлылыгы бетеп, артык ныклы кору. *Әмма ләкин калку жирләр дә бөтенләй кибеп бара, хәтта тузаннар да очкалый.* Ш. Камал. *Күз аллары караңгылана, башы зыңлый, теле, тамак төбе, бөтен авыз эче чатнап кибә.* Г. Гобәй. || Парга әйләнү (дым, сыеклык, су турында). *Июль числосының эсселегеннән, --- чокырларда булган сулар кибеп, чокыр бөтенләй тузанга әйләнеп, һаваны тузан илә тутырадыр иде.* Г. Коләхметов.

2. Кору, тереклек итүдән туктау (үсемлекләр турында). *Дрем кипте, корды.* М. Җәлил.

3. *күч. сөйл.* Ябыгу (авырудан, авыр эштән, төрле рухи кичерешләрдән). *Мәликә көннән-көн кипте, ко-*

рыды, хәлсезләнә барды. Г. Галиев. || Кемгә дә булса мәхәббәт тотып газаплану. [*Габделбасыйр:*]—*Диләфрүз белән гыйшык тотышабыз. Ул да саргаеп, кибеп бетте, мин дә, менә үзең күрәсең, көннән-көн саргаям, кибәм.* Ф. Әмирхан.

◊ **Кипкән балыкка әйләнү** — бик нык ябыгу. *Дүрт-биш көн эчендә [Вәли] үзе кипкән балыкка әйләнде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КИГЕЗҮ *ф. к.* кидерү. *Малайның башына чиккән кәләпүш кигезделәр.* М. Гали.

КИГЕРҮ *ф. диал. к.* кидерү. *Көн саен ул аңа апак чиста күлмәк кигерә.* М. Җәлил.

КИГИ *и.* Тәгәрмәч тырнагы. [*Үзле балчык*] *зур-зур кантарлары белән кубып тәгәрмәчкә ябыша, тугымнар, кигиләр, калынаеп, резинадан эшләнгән төскә керәләр.* Л. Гыйләҗев. || Гомумән шуңа охшаш нәрсәләр турында.

КИГӘВЕН *и.* Личинкасы хайваннар тәнендә яши торган ике канатлы паразит бөҗәк. *Сыерлар, яртылаш су эченә кереп, өсләренә кунган кигәвеннәрне койрыклары белән кугалыйлар.* Ә. Айдар.

КИДЕРҮ *ф.* 1. Кемгә дә булса берәр төрле кием кияргә ярдәм итү. *Нинаять, иске-москы бишмәтләрен, тишек кигез каталарын кидереп, Габдулланы арбага чыгарып утырттылар.* Ә. Фәйзи. [*Ана*], *одеялның бер читен ачып, сыңар өзкбашны улының таза аягына кидерде.* А. Шамов. || Берәр әйберне тышлык эченә тыгу, тышлык белән каплау. *Мендәргә тыш кидерү. Диванга чехол кидерү.*

2. Эче божра сыман куыш әйберне нәрсәгә дә булса кертү, урнаштыру. *Йөзек кидерү. Камыт кидерү.* □ *Кызлар муенсаны Алтынчәчкә кидерәләр.* М. Җәлил.

3. (Кармакка җим) утырту. *Мосафиров секретарьның кармагына суалчан гына кидереп торган.* И. Гази.

КИЕЗ *и.* Йоннан басып эшләнгән тыгыз материал. *Чиста итеп юылган такта идәнгә сары төстәге иске киез җәелгән.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Шундый материалдан эшләнгән, ясалган. *Киез тирмә.* □ *Галәк бабай Галимә апа китереп биргән урындыкка утырды да киез эшләпәсен салып тезләренә куйды.* Г. Әпсәләмов.

Киез итек — йоннан басылган итек. *Тимергали агай ферма сарыкларыннан алган йоннан ун пар киез итек бастырып, берничә кыска тун тектерде.* Г. Бәширов.

КИЕЗЛӘНДЕРҮ *ф.* Чуалту, басылдыру (чәч, йон турында).

КИЕЗЛӘНҮ *ф.* Чуалып бетү, басылу (чәч, йон һ. б. турында). [*Салихның*] *кара чәчләре чуалып киезләнгән.* Г. Мөхәммәтшин. *Киезләнеп бәткән каты мендәрдә ятса да, матур төш күрә Гәрәй.* А. Гыйләҗев.

КИЕЗЛӘТҮ *ф. к.* киезләндерү.

КИЕЗЧЕ *и.* Киез эшләүче, киез басучы.

КИЕК *и.* 1. Кыргый кош яки җәнлек. *Куанып йөгерә киек иркен чүлдә.* Дәрдмәнд. *Урман киексез булмас.* Мәкаль. || *с. мәгъ.* Кыргый. *Биектә, киек казлар отряды --- көнчыгышка таба үтеп бара.* И. Гази.

2. Ерткыч хайван. *Тирә-якта коточкыч юлбарыс, арслан, киекләр тавышы.* Һ. Такташ.

Киек каз юлы *астр.*— *к.* каз юлы.

КИЕКЛЕ *с.* Киекләре күп булган, киеккә бай (урман, кыр) һ. б. *Тау битен япкан киекле урман.* Ш. Маннур.

КИЕЛГӘН *с.* Яңа түгел, инде киюдә булган, таушалган. [*Фазыйл*] *кулына бераз киелгән --- бер камзул тоткан.* Г. Ибраһимов.

КИЕМ I *и.* 1. Тукымадан, күннән, мехтан. һ. б. ш. әйберләрдән тегелгән, эшләнгән һәм тәнне каплау өчен хезмәт итә торган предметлар җыелмасы. *Энесен яхшы киемнәрдә күрү Газизә өчен зур куаныч булды.* Ә. Фәйзи. *Кием кешене бизәсә дә гүзәл итмәс.* Мәкаль. || Пальто, бүрек, итек һ. б. ш. тыштан киелә торган җылы киемнәр; тышкы кием.— *Ничек оялмыйсың, Камил, киемнәрең белән йокларга?* Һ. Такташ. *Киемнәре бөрәр кат чикмән белән иске генә башмәттән гыйбарәт булган бу ярлылар --- кайтып китә башладылар.* М. Гафури.

2. *күч. шигъ.* Гадәттә билгеле бер урынның, агачларның яшеллек белән капланулы турында әйтелә. *Йомшак нурларын сибә-сибә килә май, яшел киемнәрен кия киң тугай.* Ә. Ерикәй. *Бары Агыйделнең аръягындагы чыршы-нарат урманы гына үзенең яшел киемен салмаган.* Г. Гобәй.

Кием элгеч — киемнәр элә торган урын яки махсус җайланма. [*Кыз*] *пальтосын кием элгечкә биргәч, залга узышлый, дхмәт янына тукталды.* Г. Минский.

◊ **Кием калыбы** — 1) *к.* манекен; 2) *күч.* кулыннан бер эш тә килми торган, киенеп-ясанып кына йөри торган кеше.

КИЕМ II Бер бөтен әйбер (комплект) тәшкил итә торган һәм бергә генә файдаланыла торган ике бер төсле һәм бер иш предметлар турында әйтелә; пар. *Бер кием перчатка. Ике киезм ботинка.* □ *Бер кием читекне каеган өчен биш тиен бирәләр.* М. Гали.

КИЕМ-КИЛБӘТ *җый. и.* Өс-баш, тышкы кыяфәт, киенү рәвеше. *Кәбир әфәнде --- буй-сыны, кием-килбәте, үзен тотуы, сөйләшүе белән шәкертләр һәм хәлфәләрнең исен китәрде.* Ә. Фәйзи.

КИЕМЛЕК *и.* 1. Кием тегү өчен булган тукыма. *Сәмигыл абзыйның --- үзенә, хатынына, бөтен балаларына киемлекләр, тоз, шырпы, сабын һәм бер самовар бирделәр.* М. Гали. || *с.* Кием тегәргә яраклы, кием тегә торган. *Киемлек товар.*

2. Кием булу сыйфаты. *Үзе адәмлектән чыккан-ның, киеме киемлектән чыгар.* Мәкаль.

КИЕМ-САЛЫМ *җый. и.* Өс, баш, аяк киемнәре җыелмасы. *Шәмгун картка егетнең төсе-бите дә, хәтта кием-салымы да ошады.* А. Шамов. *Хуҗалык командасы --- кием-салымнарын ташып куйган.* Ш. Усманов.

КИЕМ-ТОТЫМ *и. сөйл. к.* кием-салым. [*Капитан:*] *Ашау-эчү, кием-тотым бездә алар кечкенә мәсьәлә.* Ш. Камал.

КИЕМЧЕ *и. иск.* Кием тегүче. *Хөсәен --- озын казаки кими, бәлки озынрак кына, татар киемчесе теккән пиджак киеп йөри.* Ф. Әмирхан.

КИЕНДЕРҮ *ф.* 1. Кемгә дә булса киенергә ярдәм итү, кием кидерү. *Хәмидә әби [Галимә апаны] киендерү җаен карый.* М. Гафури. || Кемгә яки нәрсәгә дә булса охшатырга тырышып кием кидерү. *Маратны --- Ленинның сабый чагындагы кебек итеп киендергәннәр.* Г. Гобәй. *Тыңла: Без сине кыз итеп киендерербез.* М. Җәлил.

2. Кием белән тәэмин итү, кием булдыру. *Кечкенә бала көннәремдә, һичбер эшкә ярамасам да, атаманам мине киндереп асрап үстерделәр.* Дәрдмәнд. || Матур кием белән тәэмин итү, матур итеп йөртү. *Киендерсәң киндер таягы да кияү була.* Мәкаль.

КИЕНҮ *ф.* 1. Нинди дә булса кием кию. *Аннанмоннан киендем дә, тизрәк урамга чыктым.* М. Әмир. || Үзеңә кием булдыру, үзеңне кирәкле киемнәр белән тәэмин итү.

2. Матур, яхшы киемнәр кию, купшыланы. *Гөлниса белән Фатыйма да бик киенгәннәр иде.* Ш. Камал. *Киенә белү — зур осталык.* Азат хатын.

3. *күч.* Нәрсә белән дә булса каплану, өртелү (гадәттә агач, җир һ. б. турында әйтелә). *Май айлары, Бөтен дөнья яшел киемнәргә киенгән.* Һ. Такташ.

КИЕНҮ-ЯСАНУ *ф.* Матур, купшы итеп киенү, бизәнү, купшылану. *Гыйльметдин үзе шулай, киенеп-ясанып, сакал-мыегын буятып килгән.* К. Нәҗми.

КИЕРГЕ *и.* **1.** Чигү чиккәндә тукыманы тарттырып куя торган рам формасындагы җайланма. [*Ана*] *кечкенә киергесен тезенә куеп кульяулык чигә.* Г. Бәширов. *Тамбур киергеләрем бөгелмә, Бөгелмәдән килгән түгелме?* Җыр.

2. *к.* киергеч 2.

КИЕРГЕЧ *и.* **1.** Нәрсәне дә булса җәеп, киереп кую өчен булган җайланма. *Д Фәүзия киергечкә Зур кунычлар киертә.* Ш. Маннур.

2. *Махс.* Тиресе салдырылып кына алына торган хайваннарның тиреләре эченә куеп, тирене киереп киптерү өчен кулланыла торган ике аерылы агач. *Вәлинең йорт җиһазлары төрле мылтыклардан, төлке аулый торган флаглар, куян тиресе киергечләреннән тора иде.* Х. Госман.

КИЕРГЕЧЛӘҮ *ф.* Нәрсәне дә булса киерү, киергечкә тарту.

КИЕРЕЛҮ *ф.* **1.** Киңәю, кабару. [*Атның*] *йодрык сыярлык киерелгән тананарыннан атылып чыккан эссәлек Газинурның битенә бәрелде.* Г. Әпсәләмов. *Хәлимнең күлмәге, җилдә кабарынып, җилкән кебек киерелде.* И. Гази.

2. Бертөрле торышта, хәлдә озак булып оеган, арыган гәүдәне, аяк-кулны язу. *Зур сандык өстенә җәелгән йомшак түшәккә яткан Габдулла рәхәтләнеп бер киерелеп куйды.* Ә. Фәйзи. *Гәрәй урынныннан торып тәмле генә бер киерелде.* Ш. Усманов.

3. Киеренкеләнү (нервлар турында). *Салихның киерелгән нервысы бераз бушанды.* Г. Минский.

4. *рәв. мәгъ. күч.* **киерелеп**. Барлык көчкә. [*Закир:*] *Мин дулкында киерелеп ишәргә яратам.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

5. *рәв. мәгъ. күч.* **киерелеп**. Батырланып, дәртләнеп. [*Шәмсетдин*] *хәзер үзе шәһәр алгандай киерелеп атлый, хәзер аның тавышы да, сүзләре дә дәртле... гайрәтле иде.* Г. Бәширов. || Масаеп, һаваланып, горур. *Бер бай бара чабып, киерелеп, киеп толып.* Г. Камал.

КИЕРЕНКЕ *с.* **1.** Зур көч, энергия куюны, сарыф итүне сорый торган; зур көч, игътибар таләп ителә торган. *Киеренке хезмәт.* □ *Берничә көнгә сузылган авыр, киеренке эш вакытында һәркем инде ярыйсы гына йончылырга да өлгерде.* Н. Фәттах. *Шәһәр киеренке тормыш белән яши.* Х. Садри.

2. Билгеле бер хәлдән чыгу юлын таләп иткән, чишелеш кирәк булган, авыр, кискен. *Киеренке халыкара хәл.* □ *Киеренке вакыйгалар, җыелыш, митинглар ыгы-зыгысыннан арган гәүдәләргә ял биреп, нарларга яткач та, бик озак барды әңгәмә.* К. Нәҗми. || *күч.* Бик тар, аз (вакыт турында). *Вакыт киеренке, эш тыгыз.* Ш. Камал.

3. Табигый булмаган, уңайсыз, тартынкы, күңелсез. *Киеренке сөйләшү. Киеренке очрашу.* □ *Өстәл янында берничә минут киеренке тынлык хөкем сөрде.* Г. Ахунов.

КИЕРЕНКЕЛЕК *и.* Киеренке булу хәле. *Бу йортта* [*райкомда*] *үзенә хас басынкы бер киеренкелек, җитди бер эшчәнлек сизелеп тора.* Г. Бәширов. *Менә зур киеренкелек белән беркадәр шикләнеп көткән секунд җитте.* А. Шамов.

КИЕРЕНКЕЛӘНҮ *ф.* Киеренке хәлгә килү, киеренкегә әйләнү. *Нәтиҗәдә көннең-көн буена утырып оешкан әгъзалары язылып, киеренкеләнгән нервлары тынычланып, ятуга изелеп китә торган булды* [*Хәлим*]. Г. Гобәй.

КИЕРМӘ *с.* Зур булып киерелгән. [*Булат:*] — *Чабатамы, киермә борын!* К. Тинчурин.

КИЕРТҮ *ф. к.* кидерү. *Лалә* [*Шәрәфнең*] *бармагына балдак киертә.* М. Фәйзи. *Күңелсезгә күлмәк киертмиләр.* Мәкаль.

КИЕРҮ *ф.* **1.** Тарту, сузу (җәя керешен). *Җик, укны алып, калкурак җиргә баса да җәядән киереп хан сарае ягына атып җибәрә.* М. Җәлил. || Берәр нәрсәне сузып, тартып читләреннән, кырыйларыннан кая да булса беркетеп кую. *Без чи тиреләрне киртәгә элеп киптергәндә киереп куяр өчен чәй очлый идек.* М. Гафури.

2. Кабарту. *Җил җилкәнне киерде, көймә шактый кызу йөзеп китте.* Г. Әпсәләмов.

3. Киң итеп, зур итеп ачу. *Күршеләрнең кызгылт этәче читән башына шап-шоп сугып, бугазын киереп кычкырды.* И. Гази. *Кечерәк кенә чаптар ат, колакларын шомартып, тананларын киереп, саженьнан саженьга атылып, мәйданга килеп тә керде.* М. Гали. || Як-якка җәю, тырпайту. *Көрәшчеләр кебек, терсәкләрен киереп, алпан-тилпән атлаган була* [*Илгизәр*]. Г. Бәширов.

4. Алга чыгару, калкыту (күкрәкне, аяк һ. б.). [*Габдулла*] *ксмтлы бүрек кидем, инде камалы тун гына киясе калды, дип, пуф-пуф! итеп, корсагын киереп йөрде.* Ә. Фәйзи. *Фәрит күкрәген киерде.* Г. Гобәй.

5. *күч.* Киеренке хәлгә китерү, киеренкеләндерү. *Доктор, акыл җебен ныкыерган хәлдә, Яшәү тамырын капшый Авыру, зәгыйфь тәндә.* М. Җәлил.

КИЗИЛ *и. бот.* **1.** Көньякта үсә торган сары чәчәкле каты үзагачлы куак.

2. Шул куакның куе кызыл төстәге, авызны камаштыра торган ачы җимеше.

КИЗЛӘҮ *и. диал. к.* чишмә. [*Егет:*] — *Д Нәфисәне бер көнне генә кизләү башында очраттым.* Ф. Бурнаш. *Эре-эре яфраклар белән капланган чокыр төбендә тоныкына су ялтырый иде.— Бу бит Хәйри кизләве.* А. Гыйләҗев.

КИЗӘК *и. диал.* Кипкән сыер тизәге (ягулык урынына файдаланыла). *Көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, --- арык кына бер әби кизәк җыеп йөри.* Ә. Еники. || Кирпеч формасында кисеп киптерелгән тирес (урмансыз урыннарда ягулык итеп кулланалар).

КИЗӘҢҮ *ф.* **1.** Сугу өчен селтәнү, кул күтәрү. *Ул бит миңа да кизәнде.* М. Әмир. *Сафа, сугарга теләгән шикелле кизәнеп, борын астыннан гына мыгырдап алды.* А. Шамов.

2. *күч.* Янау, куркыту. *Атом белән кизәнү.*

3. *рәв. мәгъ.* **кизәнеп**. Киерелеп, каерылып, тулы көчкә. *Кемдер, каты кизәнеп, сакчының башына таяк белән сукты.* И. Гази.

КИЗҮ I *с.* **1.** *иск.* Дежурный. *Шау-шу ишетеп булса кирәк, кизү врач килеп керде.* Ш. Камал. *Кизү малай стена буена куелган кечерәк бер такта сандык янына --- берничә мендәр китереп салды.* М. Гали. | *и. мәгъ. Д Акмаловны солдатлар торган землянкага даими кизү итеп билгеләде.* Ә. Еники.

2. *и.* Кыек килешләрдә: дежурлык, дежур тору хезмәте. *Икенче* [*рота*] *кизүгә билгеләнеп, аңарга винтовкаларын ташламыйча торырга боерык бирелде.* Ш. Усманов.

Кизү көтү — кизүлек эшен башкару, үтәү. *Мәдрәсәдә һәр көн бер шәкерт кизү көтә.* М. Гафури.

КИЗҮ II *и.* **1.** *сөйл.* Эпидемия. [*Минһаж:*] — [*Чебиләр*] *тәгәрилә диген, кизүдәнме, үләттәнме, әллә ачлыктанмы?* К. Тинчурин.

2. Чираттагы авырту, өянәк. [*Нәбиулла:*] — *Бүселемнең кизүе кузгалды.* Т. Гыйззәт.

КИЗҮЛЕК *и.* Дежурлык, дежур тору хезмәте. [*Бибкәй:*] *Мин мәдрәсә тормышы белән таныш, самоварчы малай булырбыз, кизүлеккә ялланырбыз.* Т. Гыйззәт.

КИЙ *и.* Бильярд таягы. *Заһид бит аңа бары бер генә тапкыр кийны тоттырды, үзе күз ачып йомганчы бер-бер артлы шарларны лузаларга төшереп торды.* А. Расих. *Сөяк кебек ялтырап торган шома кийны буйдан-буйга гына түгел, очындагы бер тиен зурлыгындагы күненә кадәр мул итеп акбурлыйлар.* М. Хәсәнов.

КИКЕРЕК *и.* Ашказаныннан авыз аркылы чыга торган газ (физиологик нормаль булмаган күренеш).

КИКЕРҮ *ф.* Ашказаныннан авыз аркылы газ чыгару. [*Бай*] *елкы итен күп ашаган булса, „гылдыр-гылдыр" кикерә.* Ш. Мөхәммәдев.

КИКРИК *и.* Кайбер кошларның башларындагы итләч үсенте. *Алда кып-кызыл кикрикле, симез, ап-ак бер тавык килә.* Ә. Айдар. || *күч.* Тау сырты турында. [*Кавказда*] *томанны тишеп югарыга сузылган тау кикрикләрендә --- күзләрне камаштырып ак кар ята.* Г. Ахунов.

◇ **Кикриген кису** — *к.* кикриген шиндерү. *Шагыйрьнең күзендә сарказастик чаткы пәйда була. Белеп тор,* [*берәрсенең*] *кикриген кисмичә калмый.* И. Рәмиев. **Кикриген шиндерү** — 1) кемнең яки нәрсәнең көчен, дәртен кимету. *Шиңдердек без* [*дошманның*] *кикриген, Азау тешен алдык суырып.* Ш. Маннур; 2) (тәнкыйтьләп, куркытып) кемнең дә булса тәкәбберләнүен бетерү, масаюын кимету. **Кикрик кызару** — 1) эшләр яхшы бару, зур канәгатьлек белән яшәү. [*Сәйфи*] *колхоз димәде, колхоз өчен янып-көеп йөрмәде, үз кикриге кызаргач, аңа шул җитте.* Г. Бәширов; 2) исерүе җиткән кешегә карата әйтелә. **Кикрик шинү** — 1) кемнең яки нәрсәнең көче, дәрте кимү. *Кышның кикриге бик тиз шиңде.* Каз. утл.; 2) (тәнкыйть яки куркыту сәбәпле) кемнең дә булса тәкәбберләнүе бетү, масаюы кимү. [*Әхбәрнең*] *каршысына малайлар да килеп баскач, кикриге тәмам шиңеп төште.* Г. Гобәй.

КИКРИКҮК *аваз изд.* Әтәч кычкырган тавышны белдерә. *Таң ата бугай, әтәч кычкыра: — Кикрикүк, кикрикүк!* М. Җәлил. *Больница коймасына басып кычкырган кызыл әтәчнең кикрикүге авылның бер башыннан икенче башына кадәр тибрәнә-тибрәнә яңгырады.* Г. Әпсәләмов.

КИЛБӘТ *и.* Тышкы күренеш; буй-сын, кыяфәт. [*Мостафинда*] *таза, көчле иргә хас әлекке мәһабәт сын, горур килбәт юк иде.* Ә. Еники. *Килбәте нинди, күләгәсе шундый.* Мәкаль.

КИЛБӘТЛЕ *с.* Матур, күркәм күренешле; килешле. [*Саниянең*] *борыны кешенекеннән бер дә ким түгел, бик килбәтле, бик матур ич.* М. Шабай. *Килен килбәтле булсын, сүзе ширбәтле булсын.* Мәкаль.

КИЛБӘТЛЕЛЕК *и.* Килбәтле булу.

КИЛБӘТЛӘНЕП *рәв.* Масаеп, һаваланып. [*Яшь байлар*] *һәммәсе үз алдына бертөрле эрелек белән ложаларда яисә алгы рәт креслоларда килбәтләнеп утыралар.* Ш. Камал.

КИЛБӘТСЕЗ *с.* 1. Тышкы күренеше ямьсез, кыяфәтсез булган; килешсез. *Өйалды ишегендә чәчләре чуалган, яланаягына резина галош эләктергән, килбәтсез һәм изелгән кыяфәттә дпипә үзе күренде.* Г. Бәширов.— *Бу килбәтсез, тупас нәрсә урынына матур гына, җыйнак кына өстәл белән ике генә урындык куйган булсалар, нинди чибәр буласы икән.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Тупас, йогышсыз. [*Закир*] *коридор буйлап ипташләре белән йөргәндә Разия белән тигезләнгәч, диваналарча кычкырып көлә яисә нинди дә булса бер килбәтсез сүз әйтеп ташлый.* И. Гази.

2. *кис. функ.* Гаять, артык, бик. *Ике җитәкче арасындагы мондый килбәтсез киренкелекнең ахыры барыбер хәерле булып бетмәячәк.* А. Расих. *Аерылып киткәннәре килбәтсез зур бер аюга очраганнар.* А. Алиш.

КИЛБӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* Ямьсезләнү, кыяфәтсезләнү.

КИЛГӘН-КИТКӘН *җый. и.* Килүче һәм китүчеләр, килеп-китеп йөрүчеләр. [*Хәлим:*] *Килгән-киткәнне карап ят, Гөлгенә, без хәзер.* Г. Гобәй. | *с. мәгъ.* [*Фәхрикамал*] *килгән-киткән кешегә эш кушып интектереп бетерә.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КИЛДЕ-КИТТЕ *с.* 1. *к.* килделе-киттеле. — *Һай Галимҗан, һай бу килде-китте лыкылдаучы телне!* Г. Бәширов.

2. Начар, сыйфатсыз, әһәмиятсез, аннан-моннан гына эшләнгән. *Килде-китте такталарга басып төшеп-менеп йөрүе ничек кыендыр.* Р. Төхфәтуллин. | *рәв. мәгъ. Килде-китте эшләү.*

3. Гади, дәрәҗәсез, ихтирамга, хөрмәткә лаексыз. *Кунагы да бит аның килде-китте кеше түгел, бик хөрмәтле, бик газиз җан иясе.* Г. Минский. | *и. мәгъ. Бит әле миңа бер генә егетнең дә чын-чынлап гашыйк булганы юк! Кайбер килде-киттеләрне исәпләмәгәндә.* Н. Фәттах.

КИЛДЕЛЕ-КИТТЕЛЕ *с.* Мәгънәсез, ятышсыз (сүзләр һ. б.). [*Зөлфә*] *апасының сорауларына әллә ни исе китмәгәндәй --- килделе-киттеле җавапларын --- җиңел генә ата торды.* Э. Касыймов. | *рәв. мәгъ.* [*Ханым*] *башта --- минем сорауларга җавапларны килделе-киттеле генә бирде.* Г. Гобәй. || Акылсыз; акылга зәгыйфь. [*Галимә*] *килделе-киттеле бер кеше булып әйләнде.* М. Гафури.

КИЛЕ *и.* Эре бөртекле нәрсәләрне төеп ваклау өчен агач яки металлдан махсус формада ясалган савыт. *Килегә салып су төймиләр.* Мәкаль.

Киле сабы — киленең төю өчен чукмарбашлы агач яки металл җайланмасы.

КИЛЕМ *и. к.* килер.

КИЛЕМ-КИТЕМ *җый. и.* Килүче-китүчеләр; кунак. *Иртән Рәкыйп яныннан килем-китем өзелмәде.* А. Гыйләҗев.

КИЛЕМЛЕ *с. к.* килерле. *Балыкчылык кәсебенең иң газаплы һәм шуның белән бергә иң килемле дә булып саналган җылым тарту эше, быелгы путинада, „Кызыл балыкчы" колхозында да оештырылачак.* Г. Минский.

КИЛЕН *и.* 1. Улының яки энесенең хатыны. [*Хәдичә әпипәгә:*] — *Тик, кара аны, улым белән киленемә тел-теш тидерәсе булма!* Г. Бәширов.

2. Яңа гына кияүгә чыккан яшь хатын. *Уңган киленнәрең бер-бер артлы, Алма кебек уллар тапсыннар!* Һ. Такташ.

3. Гомумән өлкән буынның яшь буын хатыннарына мөрәҗәгать итә торган сүзе. [*Фәрхия:*] — *Рәхмәт инде, рәхмәт, Нурия килен, бик рәхмәт, Сәлимгәрәйгә дә, сиңа да.* Р. Ишморат.

Килен төшерү *этн.* — кияү йортына кызны бөтенләйгә алып кайту. *Берсе әйтә: Киләсе кече атнага Ногман хаҗиның кактөш мәҗлесе булачак, узган атнаны егерме сигез ат белән килен төшерделәр.* Г. Камал.

КИЛЕНДӘШ *и.* Ике туганның хатыннары. *Мәфтуха бу кунак килендәшенең уңган кулыннан аз гына да көнләшмәде.* Г. Ибраһимов. *Тыелса икән килендәшләрнең бер-берсен каенанасына чагуы.* Ш. Мөхәммәдев.

КИЛЕН-КҮНЧЕК *җый. и.* Яшь киленнәр. *Яшь киленнең күз яше кибеп җитәр-җитмәс, килен-күнчек* [*Нәфисә*не] *бик тырышып кияүгә димли башлады.* Г. Бәширов.

КИЛЕНЛЕК *и.* Килен булу хәле, килен булу. [*Мәрхәбә*] *үги каенананың күңелен алырга, туры киленлек, кардәшлек тойгыларын күрсәтергә ашыкты.* Г. Ибраһимов. [*Мавия:*] *Аның анасы мине түгел, авыл кызларын да киленлеккә яраклы тапмый.* М. Фәйзи.

КИЛЕНЧӘК *и. сөйл.* Яшь килен. *Бу атнада авылның асыл егетләре, матур кызлары, картлары, карчыклары, яшь киленчәкләре эштән соң барысы да Ык буенда булалар.* Г. Галиев.

КИЛЕР *и.* Табыш, файда. *Ризван да бит андый-мондый кеше түгел. Белеме дисәң белемле, килере дисәң килерле, дигәндәй, эш кешесе.* Г. Минский. || Акча, хезмәт хакы.— *Эшең әйбәт, килерең бар.* А. Әхмәт.

Килер җир (урын) — акча табу, булдыру мөмкинлеге.

КИЛЕРЛЕ *с. сөйл.* Табышлы, төшемле, күп түләнә торган (эш һ. б.).

КИЛЕШ I *и. сөйл.* *Килү* фигыленнән ясалган исем. [*Мәхүп:*] *Хәмидә, бер дә мәшәкатьләнмәгез, минем бер дә эчәсем килми, әле дсмабикәләрдән килешем, аларда бик озаклап чәй эчтем.* Г. Камал. — *Язның килеше шәп күренми әле,— диде Мостафа.* Ш. Камал.

КИЛЕШ II *и. сөйл.* Тышкы күренеш, кыяфәт. *Бу килештән кеше күзенә ничек күренерсең.* Ф. Хөсни. *Хәзер мәктәпнең килеше үк бүтән. Яшьләр җыелып түшәмен күтәрделәр, бүрәнәләрен, сайгакларын алыштырдылар.* Г. Гобәй.

Килешен китерү — нәрсәне дә булса килештерү, формасын китерү, кыяфәтен булдыру. *Егет тә килешен китергән — тар балаклы яшел чалбар киеп җибәргән.* М. Хәсәнов.

КИЛЕШ III *бәйл.* Үзеннән алда килгән сүз белән бергә кемнең яки нәрсәнең нинди хәлдә, нинди рәвештә булуын аңлата. *Маһибикә, мине җитәкләгән килеш, сөйләнә-сөйләнә керде.* М. Әмир. *Менә мин дә яшь килеш үзебезнең авылның койрык чәнчеп уйнаклый торган бозауларын бага башладым.* Ә. Айдар.

КИЛЕШ IV *и. лингв.* Исемнәрнең башка җөмлә кисәкләренә бәйләнешен күрсәтә һәм төрләнү формаларында чагыла торган грамматик категория. *Татар теле грамматикасында килеш — күп күләмдә кулланыла торган грамматик категорияләрнең берсе.* В. Хангилдин.

КИЛЕШЕНҮ *ф.* Сөйләшеп килешү, уртак фикергә килү. *Д бер көнне кызый килешенгән вакытка, килешенгән урынга килми калды.* Н. Фәттах. *Либреттоның темасы һәм планы, алдан ук ТАССРның сәнгать эшләре идарәсе белән килешенеп --- либретточылар һәм композиторлар киңәшмәсендә тикшерелгән иде.* М. Җәлил.

КИЛЕШ-КИЛБӘТ *җый. и. к.* килбәт. *Фазыл атлы иде ул яшь егет, матур иде килеш-килбәте.* З. Мансур.

КИЛЕШЛЕ *с.* 1. Килешеп торган, матур, җыйнак (кием һ. б.). *Ганбар керә. Киемнәре гади генә, ләкин килешле.* М. Фәйзи. *Зәйнәпнең килешле гәүдәсе, килешле кыланышлары аны бигрәк күркәм итә иде.* М. Гафури. | *рәв. мәгъ. Чәчәк бәйләме, хәзерге вакытта үсә торган чәчәкләрнең һәр төрлесеннән оештырылып, килешле төзелгән, матур бәйләнгән иде.* Ф. Әмирхан.

2. Фикергә туры килә торган, урынлы, сүз сөрешенә яки обстановкага яраклы (сүз һ. б.). *Кәли дә --- берәр сүз әйтергә уйлады, ләкин килешле сүз таба алмады булса кирәк, яңадан әкрен генә җиргә тезләнде.* Г. Гобәй. || *рәв. мәгъ.* Оста, төзек итеп, игътибарны җәлеп итәрлек, кызыклы итеп (сөйләү турында).]*Зыя*] *үзләрендә бала караучы булып торган Бәдри әбинең шома вә килешле рәвештә сөйләгән әкиятләрен бала чагында бик яратып тыңлый.* Г. Ибраһимов.

3. *рәв.* Әдәпле, тәртипле, күркәм. *Үзен килешле тоту.* □ *Нәбиуллин бусагадан атлауга, солдат, гадәте буенча, килешле генә иттереп үкчәләрен бәреп, кулын күтәреп честь бирде.* А. Әхмәт.

КИЛЕШЛИ *рәв.* Килү уңаенда, юл уңаенда. *Совхоздан килешли, юл киемендә Илдар керә.* М. Җәлил. *Үзләренең вагонына кайтып килешли кемдер "Гөлнур" дип дәшкән кебек булды.* Г. Ахунов.

КИЛЕШСЕЗ *с.* 1. Ямьсез, матур түгел. *Җәлеп йоклаган шикелле ята торган Каспий диңгезе арасында, киң генә тигез җирдә, тимер юл станциясенең килешсез кызгылт биналары --- кызганыч булып күренәләр.* Ш. Камал. | *рәв. мәгъ. Чал мыеклы полицмейстер --- бүген генә кырынган ияген әллә ничек килешсез селкетеп кычкырды.* К. Нәҗми.

2. Әдәпсез, тәртипсез, начар. *Юлларда килешсез тәртипсезлек хөкем сөрә.* Ф. Әмирхан. | *рәв. мәгъ. Гыйльмуллә килешсез генә көлеп җибәрде.* Ш. Камал.

КИЛЕШСЕЗЛЕК *и.* 1. Килешсез, ямьсез булу.

2. Тәрбиясезлек, әдәпсезлек. *Без өчәвебез дә бик зур килешсезлек эшләгән кешеләр кебек ни эшләргә белми аптырашта калдык.* М. Гафури.

КИЛЕШСЕЗЛӘНҮ *ф.* Тәртипсезләнү, үзен әдәпсез, ямьсез тоту, затсызлану.— *Килешсезләнеп йөргәнче, әнә бүрегеңне җыештырып куй.* Ф. Әмирхан.

КИЛЕШТЕРҮ I *ф.* 1. Ризалату, нинди дә булса фикергә күндерү.— *Ярар, ярар, кодача, сезнеке минем өстә калмас,— диде ул һәм, шуның белән Җиһанны килештердем дип уйлап, --- ындыр ягына таба кузгалды* [*Хафиз*]. Ә. Фәйзи.

2. Дуслаштыру, татуландыру. *Муйнаклары гүя боларны килештерергә телгәндәй, чиный-чиный, әле Солтан янына, әле дпипә янына чабып килә.* Г. Бәширов. *Ахырда, типография эшчеләре союзыннан ике вәкил килеп, хуҗа белән эшчеләрне килештерделәр.* Ш. Камал.

КИЛЕШТЕРҮ II *ф.* 1. Бик килешле итеп, яхшы итеп эшләү, әйтү, урынлы әйтү, булдыру. [*Сибгать*] *килештердең, Хәмзә. Молодец.* М. Фәйзи. || *рәв. мәгъ.* **килештереп.** Матурлап, матур итеп, җайлап, килешле итеп (сөйләү, язу, киенү һ. б.). *Д Гөлнаргә бүген үк үзем килештереп хат язам.* Ә. Айдар. *Карт сүзне кайнар һәм килештереп сөйләгәнгә күрә, тыңлаучылар ялыкмый гына утыра иделәр.* Ш. Камал. [*Зәйнәп*] *барлы-юклы киемнәрен килештереп, ыспайлап киенә ала.* М. Гафури.

2. Нәрсәнең дә булса формасын китерү, кыяфәтен булдыру. [*Зөләйха Галләмгә:*] *Әмма кыяфәтне дә килештергәнсең. Һичбер танырлык түгел.* М. Фәйзи.

3. Ошату, ярату, хуп күрү. *Габдулла сүзсез, йомышсыз тик утыруын килештермәде.* Ә. Фәйзи. *Сабир абзый, Сәйфулланы улы кебек күргәнгә, беренче чәйдән үк аракы белән сыйлауны килештермәде.* Ә. Еники.

КИЛЕШЧӘ *рәв. к.* килеш III. *Менә хәзер үк капкадан килеп чыгар, яисә менә хәзер ул, капка янына килеп, аннан чыгар-чыкмас кына килешчә карап тора башлар.* Ф. Әмирхан.

КИЛЕШҮ I *ф.* 1. Дус булу, тыныч яшәү, бер-береңне аңлау, бергә яши алу. *Туган белән туган куанышыр, Хатын белән ир дә килешер.* Ш. Маннур. *Фәтхия, яхшы күңелле, юаш ана булса да, киленәре белән гомере барынча килешә алмый йөдәде.* Г. Ибраһимов.

2. Дошманлашуны, талашны туктату, бетерү; дуслашу, татулашу. *Байтирәк белән Аланбаш бары Со-*

вет власте урнашып, колхозлар оешканнан соң гына килешкәннәр. Г. Бәширов. [*Габдулла агай:*] *Талашырларымы, килешерләрме — анысы яшьләрнең үз эше.* Ф. Хөсни.

3. Солых төзү. *Патша хөкүмәте илдә күтәрелеп килүче революциядән котылу өчен немецлар белән сепаратный рәвештә килешергә хәзерләнә.* К. Нәҗми. || *и. мәгъ.* Солых. *Солых дигәне шул килешү инде,— диде Шәрифҗан.— Килешү турында декрет кабул ителгән.* И. Гази. || *и. мәгъ.* Дошман лагерена карата килешүчәнлек мөнәсәбәте; принципсыз ташламалар. *„Әйче ипташлар! Бернинди дә килешүгә бармаска, капиталист хуҗалар белән башланган көрәшне ахырына кадәр дәвам иттерергә“.* Т. Гыйззәт.

4. Кемнең дә булса фикерен, тәкъдимен, сүзен дөрес дип табу; шуңа кушылу, риза булу, күнү.— *Мин Сәгыйтьҗан әфәнденең фикере белән бик, бик килешәм.* Ә. Фәйзи. || *рәв. мәгъ.* **килешеп.** Үзара алдан сөйләшеп, риза булып, бер фикергә килеп. [*Маликов:*] *мәсьәлә сезнең урынбасарыгыз белән килешеп эшләнде.* А. Әхмәт.

5. Берәр нәрсәгә карата түземлелек, чыдамлылык белән карый башлау; берәр төрле хәлгә буйсыну, күнү. *Улының өйләнүе белән килешү.* □ *Күрәсең,* [*Мостафин*] *тау кадәр газап йотып, ахыр чиктә үзенең язмышы белән килеште.* Ә. Еники.

6. Сатулашып, әйбернең бәясе турында ризалашу. *Теге кеше башта егерме тиен биреп сатулашса да, соңыннан утыз тиенгә килештеләр.* М. Гали. *Шәрифулла мичне төзәтергә кирәк тапты, шунда ук алар бәясен дә килештеләр.* А. Шамов.

7. Ярәшү; өйләндерү яки кызын бирү турында сөйләшеп кую, ризалашу. *Нурмөхәммәт бабай берәүгә дә белдермичә* [*кызын*] *Бикъярның Шибай кантун улына килешкән дә куйган.* Г. Ибраһимов.

КИЛЕШҮ II *ф.* **1.** Ятышлы, килешле булу (кием, өс-баш кыеме, бизәнү һ. б. турында). *Карлы чәчләр сиңа килешә, Алсу. Үз чәчеңнән матур булганнар.* Һ. Такташ. *Ал кием безнең Хәяткә бик килешә.* Ф. Әмирхан. || Ошау, тиң булу, кулай булу, туры килү. *Чибәр егетләргә чибәр кызлар килешә.* Г. Камал.

2. Төгәл, әйбәт, бар яктан килү. *Зөһрә матур судан кайта, Күлдән түгел — инештән; Бөгелми дә сыгылмый да, Бар җире дә килешкән.* Х. Мөҗәй. || Әйбәт, яхшы сыйфатлы булу, тиешле дәрәҗәдә булу. *— Юк, юк, борчылмагыз, без ашыйбыз, ашларыгыз бик килешкән,— диде берничә тавыш берьюлы.* Г. Әпсәләмов.

3. Урынлы булу, яхшы булу, ятышу, ярау (берәр төрле эш, хәрәкәт, сүз турында). [*Әнвәр:*] *Мәдинә, миңа һаман сез дип эндәшәсең... Ике ел буена таныш кеше белән алай сөйләшү килешеп җитми.* К. Нәҗми. *Ни эшләсәк, шул килешә, әмма рәхәт яшь чакта.* М. Фәйзи.

4. Уңай тәэсир ясау, шифалы булу, ярдәм итү. *Берәүгә — бер, берәүгә бер дару килешә.* Г. Гобәй. *Каушау килешә икән тагын үзенә: ике бите алма төсле булып кызарды.* Ф. Хөсни.

◇ **Килешмәгән як (җир)** — кимчелекле як, кимчелек. *— Шаян син, Миңнурый. Гел кешеләрдән көләсең. Әйтерсең, үзеңнең бер дә килешмәгән ягың юк,— диде Сәлим.* Г. Әпсәләмов. **Килешмәгән эш** — ярамаган эш, начар эш. *Зөләйха абыстай исә мулласының шундый килешмәгән эше өчен кеше алдында кызарып җаны чыга.* Г. Ибраһимов.

КИЛЕШҮЧӘН *с.* Килешүгә бара торган, ризалашучан, сүз тыңлаучан, буйсынучан.

КИЛЕШҮЧӘНЛЕК *и.* **1.** Килешүчән булу. [*Михайлов Салаваттан:*] *— Ата беләсеңме соң? — дип сорады. Хәзер инде аның тавышында килешүчәнлек һәм ягымлылык бар иде.* А. Шамов.

2. *полит.* Принципсызлык, аумакайлык. *Меньшевикларның килешүчәнлек политикасы.*

КИЛКИ *и. сөйл. к.* килька.

КИЛМЕШӘК *и. гади с.* Каян булса да килгән, чит кеше. *Д Каюм абзый кем соң? Әхмәт кем? Читтән килгән килмешәкләр.* Ш. Камал. [*Әбүзәр:*] *Мин килмешәк түгел, шушы җирнең кешесе.* Т. Гыйззәт.

КИЛО *и. сөйл. к.* килограмм. *Капчыгыннан ул йөз грамм яхшы чәй белән бер кило чамасы шикәр чыгарды һәм Сафия абыстайга сузды.* А. Шамов.

КИЛОВАТТ *и. физ.* Электр тогы егәрлеген үлчи торган берәмлек: бер киловатта бер мең ватт була. *Алты мең киловатлы электр чыгымында замыкание булып ала.* А. Гыйләҗев. *Бер миллионнан артык киловатт электр энергиясе бирәчәк бит* [*станция*]. С. Рафиков.

КИЛОВАТТ-СӘГАТЬ *и. физ.* Егәрлеге бер киловатт булган токның бер сәгать эчендә эшләгән эшен үлчәү берәмлеге.

КИЛОГРАММ *и.* Мең граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге. *Колхоз кырларында һәр килограмм икмәк өчен авыр көрәш барды.* Г. Гобәй.

КИЛОГРАММЛАП *рәв.* **1.** Килограмм-килограмм итеп. *Килограммлап бүлү.*

2. Күпмедер килограмм чамасы, ... килограммга якын.

КИЛОГРАММЛЫ *с.* Бер килограммга тигез булган. *Килограммлы гер.*

КИЛОЛАП *рәв. к.* килограммлап. *Килолап үлчәү.*

КИЛОЛЫ *с. к.* килограммлы. *Килолы чүпрә.*

КИЛОМЕТР *и.* Мең метрга тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге. *Акчишмә суы белән Кандыр арасы күп булса биш-алты километр булыр.* К. Тинчурин. *Алтмыш километр ераклыгындагы юл сизелмәде дә.* Ә. Айдар.

КИЛОМЕТРАЖ *и.* Километрлар белән үлчәнгән озынлык, ара. [*Миләүшә*] *трассага чыгып, төрле километражларда, төрле участокларда җәелгән асфальтлардан, махсус өтерге белән китеп, пробалар ала.* М. Хәсәнов.

КИЛОМЕТРЛАП *рәв.* **1.** Километр белән. *Километрлап үлчәү.*

2. Күпмедер километрга якын, километр чамасы. *Ун километрлап бар әле.*

КИЛЬ *и. махс.* **1.** Самолет яки дирижабль койрыгының бер өлеше.

2. Судно корпусының иң аскы сырты.

КИЛЬВА'ТЕР *и. махс.* Хәрәкәт итүче судно артыннан калган су агымы. || *күч.* Бер юнәлеш, бер үк юл. *Бөтен коллективны бер кильватерга төзергә кирәк.* И. Гази.

КИ'ЛЬКА *и. зоол.* Сельдь балыклары семьялыгына керә торган вак балык. *Без, кыздырылган кильканы мактый-мактый, симез тавыкны ботарларга керештек.* Каз. утл.

КИЛӘП *и.* **1.** Орчыктан махсус агачка сарып, чуалмасын өчен бәйләм итеп уралган җеп. *Сал киләпкә, санап рәткә, Тигез сана басмасын, Таралмасын җепнең очы, Нык бәйли күр тасмасын.* З. Байчурина. *Авыл читендәге Гөлҗамал йон эрли, Киләп сара Гайфиләргә.* Н. Баян.

2. Җеп үлчәү берәмлеге, өч метр чамасы. *Бер киләп җеп.*

Киләп агачы — җеп киләпләү өчен бер башын япьле итеп, икенче башына аркылы таяк беркетеп эшләнгән бер метр чамасы озынлыгындагы махсус агач. **[Бер] киләп буе** — җеппнең киләп агачын бер мәртәбә уратып алган озынлыгы.

◇ **Киләбен чуалту** — уй, фикерне чуалту. *Бу караш Сөләйманның киләбен тагын да чуалтты.* К. Тинчурин. **Киләп сару, киләп сарып йөрү** — арлыбирле эшле-эшсез йөрү. [*Илсөя*] *кухня белән зал арасында киләп сарып йөри.* Г. Мөхәммәтшин. *Улының ферма тирәсендә киләп сарып йөрүен Җәмилә җиңгигә ишеттергәннәр иде инде.* М. Хәсәнов.

КИЛӘПЛӘҮ *ф.* Киләпкә җеп урау, киләп ясау.

КИЛӘСЕ *с.* Алдагы, булачак (вакыт яки урын турында). [*Газинурга*], *ни өчендер, киләсе станциядә Миңнурый яңадан күренер кебек тоела иде.* Г. Әпсәләмов. [*Гөлзадә:*] *Мин бит киләсе елга Мәскәүгә китәргә җыенам.* Р. Ишморат.

Киләсе буын — киләчәк буын, алдагы буын.

КИЛӘЧӘК *с.* 1. Хәзергедән соң буласы, алда булачак (көннәр, айлар, еллар һ. б.). *Нинди бәхетле! Мин үземнең киләчәк тормышымны күрәм.* Г. Кутуй. || *и. мәгъ.* Киләсе, алда булачак вакыт. *Баланың эчке дөньясы киләчәкнең якты өмете белән, изге тойгылар, яхшы уйлар белән нурланып үссен!* Г. Бәширов. *Киләчәккә юллар ачтык Бөек Октябрьда без.* Ә. Исхак.

2. Алда яшәячәк, моннан соң яши торган (кеше, буын һ. б.). *Безнең киләчәк буыннар хатын-кызларны --- кеше булган, иптәш булган, бөек төзелештә бергәләп эшләгән өчен сөярләр.* А. Шамов.

3. *и. мәгъ.* Кем яки нәрсәнең алдагы тормышы, язмышы. *Париж киләчәгe завод-фабрикаларда эшләнеп ята.* Г. Гали. *Киләчәк синең кулыңда, юлларың чәчкә генә.* С. Хәким.

4. *и. мәгъ. күч.* Алдагы көннәрдә булачак уңышлар, уңышлыклар; карьера. *Кем генә үз баласының киләчәгe белән хыялланып яшәми икән!* Г. Минский. *Пианинога кул салу* [*сату*] *турында Бибиҗамал апа ялгыш та уйлап карамады. Чөнки пианино улының киләчәгe иде.* Ш. Хөсәенов.

Киләчәк заман *лингв.* — сөйләнеп торган вакыттан соң булачак эш-хәлне, хәрәкәтне белдерә торган фигыль категориясе.

КИЛӘЧӘКЛЕ *с.* 1. Матур киләчәгe булган. *Зур киләчәкле шәһәр.* □ [*Шагыйрь*] *хезмәт иясе халкының якты тормышы, матур киләчәкле булуы турында язды.* М. Җәлил.

2. *күч.* Өметле, талантлы. *Киләчәкле яшь шагыйрь.* М. Гафури.

КИЛҮ *ф.* 1. Хәрәкәт итеп, нинди дә булса билгеле бер урынга якынаю яки барып җитү, барып керү (җәяү яки төрле транспортта). *Ана, борчылып, тагын тәрәзә янына килде.* А. Әхмәт. *Кунак килсә, үз ризыгы белән килә.* Әйтем.

2. Сөйләүчегә таба юнәлештә хәрәкәт итү. *Агыйделнең арьягыннан Атлар килә адымлап.* Җыр. || Масса, тоташ агым булып хәрәкәт итү (болыт, су, һава һ. б. ш.). *Биек тауларга менәмсең, Болыт килә күрәмсең.* Җыр. || Боз, сал, бүрәнәләр һ. б. ш. су буйлап хәрәкәт итү. *Елганың уртасыннан, чынлап та, зур боз кисәге сал шикелле агып килә иде.* Ә. Фәйзи.

3. Берәр максат белән кая булса да бару. *Эшкә килү. Киңәшкә килү.* □ *Менә җиләк җыярга килгәч, карурман эченә кереп китәр алдыннан туктап ял итә --- торган кечкенә алан.* Г. Бәширов. *Син киләсең иртән укытырга, йөзләп бала Сырып ала тирә-ягыңнан.* З. Мансур. || Хәрәкәт итү, күчү средстволары турында. *Ямьле Агыйдел буйларының бер култыгында урнашкан бу пристаньга хәтле пароход биш тәүлек килде.* Г. Минский. || Күчмә кошларның җылы яктан кайтулары турында. *Менә яз хәбәрчеләре — кара каргалар килеп, су буендагы биек таллarга, тирәк башларына оя кордылар.* Г. Гобәй. [*Хөсәен карт*] *сыерчык килгәнне көтә башлый.* Г. Газиз.

4. Билгеләнгән урынга барып җитү, тапшырылу (кая да булса жибәрелгән әйбер турында). *Җәй килде. Ә зарыгып көткән хат килмәде.* Ш. Хөсәенов. *Бүген авылдан телеграмма килде.* Һ. Такташ. || Каян да булса билгеле бер урынга әйбер китерелү, кайтарылу. *Завод коллективын хәзер ике генә нәрсә борчый: берсе — читтән киләчәк станоклар, икенчесе — тәрәзә пыялалары.* А. Расих.

5. Өстәлгә, табынга китерелү, куелу, бирелү (ашамлык, эчемлек һ. б.). *Ул арада табынга самовар килде.* М. Гали. *Шулпа артыннан — каз бәлеше, бәлеш артыннан табак өеме ит килә.* Ә. Еники.

6. Бүленеп чыгу, агу (су, кан, яшь һ. б.). *Төкерек килү. Селәгәй килү.* □ *Күңелем нечкәреп китте, күзләремә яшь килде.* Ә. Айдар.

7. Нинди дә булса урыннан таралу, чыгу, кая да булса үтеп керү (ис, төтен һ. б.). *Җир өстенә бирәү ислемай сипкән шикелле, әллә кайдан баллы чәчәк исе килә.* Ш. Усманов. *Өйдән салам көле исе, тәмле борщ исе килә.* А. Шамов.

8. Каян да булса ишетелү (тавыш, җыр һ. б. турында). *Даладан бала елаган тавыш килде.* Г. Ибраһимов. *Ерактан җыр һәм гармонь тавышы килә.* Г. Камал.

9. Файдалануга бирелү, аерым чыганакка тоташтырылу (газ, ток, су турында). *Газ килү. Ток килү.*

10. Билгеле бер вакыттан, чордан башланып дәвам итү (нәсел, гадәт һ. б.). *Борынгыны яхшы белүче картлар Акбитнекеләрне ил батыры Моратай нәселеннән килә дип сөйлилəр.* Г. Бәширов.

11. Башлану, якынлашу, җитү (ел, көн вакытлары турында). *Нурлы язлар килде.* Ә. Еники.

12. Бирелү, түләнү, алу (эш хакы, пенсия, пособие һ. б. турында). *Акча күбрәк килә торган булса, ул әле тагын бер хәл,— дип уйлап алды Галиулла,— алай булганда, барырга да мөмкин.* И. Гази.

13. Берәр төрле план, фикер, уй һ. б. барлыкка килү, туу (башта, күңелдә). *Башыма әллә ниләр килә.* Ф. Әмирхан.

14. Төгәл, җитеш булу. [*Кызның*] *акылымы дисең, эшкә уңганлыгымы дисең, телгә-сүзгә осталыгымы дисең, тагын буе-сыны дисеңме,— барысы да килгән иде.* А. Шамов. || Әйбәт, яхшы сыйфатлы булу, тиешле дәрәҗәгә җитү. *Мичебезнең төбе начар, нихәтле күп, яксаң да, икмәкнең асты килми, бераз сүрәнрәк булгандыр, ахры.* М. Гали.

15. „Хәлгә“ сүзе белән килеп, кем яки нәрсәнең берәр төрле сыйфатка күчүен, үзгәрүен белдерә. *Юллар бозылган, казылып беткән, йөри алмаслык хәлгә килгән.* А. Шамов.

16. Кайбер юнәлеш килешендәге абстракт исемнәр янында шул исем белдергән нәрсәне ачыклау, аңлап алу, төшенүне белдерә. [*Мостафин*] *күп уйлаганнан соң, яратуының чын булуына ышангач, ахырда менә бүген ныклы карарга килде.* Ә. Еники.

17. Эш яки хәлнең башлануын белдерә. *Берьюлы барлык атлар, арбалар, кешеләр хәрәкәткә килде.* И. Гази.

18. Тарту, (фәлән кадәр) авырлыкта булу. *Кәбестә ун килограммнан артык килде.* Г. Ахунов.

19. Үзеннән алдагы, чыгыш килешендәге исем (яки шул функциядәге сүз) белдергән сәбәп аркасында булу, туу. *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә.* Г. Тукай.

20. *ярд. ф. функ.* Хәл фигыльләр янында: 1) нинди дә булса предметка, урынга таба юнәлүне белдерә. *Түбән яктан өч катлы ак теплоход чыннан да бик җилле менеп килә иде.* Э. Касыймов; 2) эш яки хәл-

нең әзлекле үсешен, дәвамлылыгын, үзенең соңгы чигенә якынлашуын белдерә. *Кояш баер вакыт та җитеп килә.* Г. Камал. *Каен әле яфрак ярып кына килә иде.* А. Шамов; 3) эш яки хәрәкәтнең үткәннән хәзергегә үсешен, күчүен күрсәтә. *Д еллар яңаның җиңүен алып килделәр.* Һ. Такташ; 4) эш яки хәлнең даими рәвештә кабатлануын белдерә. *Моңа кадәр ничек эшләп килгән булсам, моннан соң да шулай эшләрмен.* Ф. Хөсни. *Ничә еллардан бирле, ничәмә миллион эшчеләрнең көче капиталистлар, изүчеләр тарафыннан таланып килә.* Х. Садрый; 5) эш яки хәрәкәтнең, юл уңаенда эшләнүен, үтәлүен белдерә. *Керә килү. Ала килү;* 6) *-асы* кушымчалы сыйфат фигыль белән килеп, нинди дә булса теләк, омтылыш барлыгын белдерә. *Минем очасым, очасым килә.* К. Тинчурин. *Уйныйсы, шаярасы, җырлыйсы килә.* М. Әмир; 7) кайбер аваз ияртемнәре белән килгәндә фигыль ясый торган кушымчалар функциясен үти (мәсәлән, гөж килү — гөжелдәү, шау килү — шаулау һ. б.). *Бәдри дер-дер килә.* М. Фәйзи. *Читтән карап торган кечкенә малайлар, чыр-чу килеп, сабанчылар артыннан йөгерделәр.* Г. Гобәй. *Урам тулы халык шау-гөр килә.* М. Гали.

Килеп керү — кинәттән, искәрмәстән керү. **Килеп тору** — 1) дәвамлы, өзлексез рәвештә чыгу (газ, су, ис һ. б.); 2) билгеле бер урында еш, һаман булу; 3) әледән-әле, регуляр рәвештә кайту (товар керү һ. б.); регуляр рәвештә алу (хат һ. б.); 4) дәвамлы, озак вакыт шул хәлдә булу. *Караңгы төшкәнче күпер башы шау-гөр килеп торды.* И. Гази. **Килеп чыгу** — 1) берәр нинди нәтиҗәгә китерү. [*Заһит Мәхмүткә:*] *Бөтен тавышка мин сәбәпче булдым кебек килеп чыга.* Ф. Хөсни. *Эш болай килеп чыкты.* Ш. Камал; 2) искәрмәстән, кинәт каян да булса чыгу, күренү; уйламаганда барлыкка килү, туу. *Лотфулла абзый буровойга төнлә килеп чыкты.* Г. Ахунов. *Кичүгә борылган юлга килеп җиткәндә, каршыбызга Зөлхиҗә килеп чыкты.* М. Әмир; 3) урыныннан чыгу, кубу. *Тәгәрмәч килеп чыкты.*

КИМ *рәв.* **1.** Җитәрлек түгел, тиешле дәрәҗәсеннән аз. [*Нәфисә:*] — *Аннары безнең бодайны ким чыгарып маташалар бит әле, әнкәй.* Г. Бәширов. *Яз җитә башлагач, ай буена көн дә берәр сәгать артык укып килделәр дә, җир сөрергә чыгу белән, икешәр сәгать ким укыдылар.* Г. Гобәй. | *с. мәгъ. Ким үлчәүле.*

2. Начар, начаррак, түбән. *Авыл дигәч тә,* [*балаларның*] *ала торган тәрбияләре шәһәрдәгедән бер дә ким түгел.* Г. Кутуй. *Мисбах --- хәзер чыбыркыны Газинурдан бер дә ким шартлатмый инде.* Г. Әпсәләмов.

3. *с. мәгъ.* Күп нәрсәләрдән мәхрүм ителгән, кемгә дә булса тиң булмаган. *Килен кеше — ким кеше.* Мәкаль.

Ким җөмлә *лингв.* — берәр баш кисәге төшеп калган җөмлә. **Ким дигәндә** — *к.* кимендә. **Ким куймый, кимен куймый** — нинди дә булса эшне тулы канәгатьләнү алырлык, кирәгеннән артыгы белән эшләү, башкару. [*Гайни:*] *Алай да андагы бай хатыннары бер дә киенүнең кимен куймыйлар.* Г. Камал. **Ким күрү** — санламау; түбәнсетү, кимсетү. *Кимсетәләр, ким күрәләр, әллә бәхетем юкка.* Җыр.

КИМВАЛ *и. муз.* Ике металл тәлинкәдән гыйбарәт музыка коралы.

КИМЕК *и.* Сөякнең җилек аралашкан йомшак өлеше. *Төше каплы, кимеге татлы.* Табышмак.

КИМЕНДӘ *рәв.* Аз дигәндә, иң азы; минимум. — *Быел безнең һәркайсыбызга кимендә өч йөз утызар хезмәт көне эшләргә туры килачәк.* Г. Бәширов. *Җитмеш яшь бар аңа кимендә.* Ф. Кәрим.

КИМЕРЧӘК *и.* Кеше һәм хайваннар организмында скелетның кайбер өлешләрен тәшкил итә торган тыгыз һәм каты тоташтыргыч тукыма. *Умырткаларның төп сөякләре бер-береннән калын һәм эластик кимерчәк катлавы белән аерылып торалар.* Зоология.

КИМЕРҮ *ф.* **1.** Нинди дә булса каты әйберне тешләр белән ваклап ашау, кырып ашау. [*Миңлебикә*], *елау аралаш, юл буенча клиндер кимереп барды.* К. Нәҗми. *Майпәрвәз ханым киявенең тәлинкәсенә итнең иң шәп җиреннән зур түтәрәм янбаш сөяген сала,— бусы кимерер өчен.* Ә. Еники. || Тешләр белән кысып чәрдәкләү, ваклау, өзү. *Елтыр соры түшле, озын койрыклы, кечкенә генә тычкан бер бодай камылын кимереп утыра иде.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Газаплау, борчу (уй, хис һ. б. ш. турында). *Гайнижамалның күңелен вакыт-вакыт әч пошуга якын бер уңайсыз тойгы кимерә.* Ш. Камал. *Дөрес, баштарак Василга кыен иде, аның бәгырен нидер кимерә иде.* С. Рафиков.

3. *күч.* Кем яки нәрсә исәбенә яшәү; урлашу. [*Сәйфи*] *шыпырт кына тик кимереп ятkан колхозны.* Г. Бәширов.

КИМЕРҮЧЕ *и. зоол.* Озын һәм нык булган алгы тешләре белән үсемлек орлыгы, агач кайрысы һ. б. ш. кимереп тукланучы имезүче җәнлек (тиен, йомран, күсе һ. б. лар).

КИМЕТҮ *ф.* **1.** Күләм, зурлык, сан ягыннан азайту, кечерәйтү. [*Шәжәг:*] *Бай, һаман миннән гаеп тапкан булып, минем жалуниямне киметергә генә тырыша.* Г. Камал. *Бәлки, эш хайваннарыннан башка малтуарны беркадәр киметергә туры килер.* Ш. Камал.

2. Дәрәҗәсе, көче, сыйфаты һ. б. ягыннан түбәнәйтү, кечерәйтү. *Ләкин М. Гафуриның әсәрләрендәге йомшак яклары аның иҗатының политик үсә баруын һәм демократик идеяләрне таратудагы әһәмиятен киметмиләр.* М. Җәлил. *Салкын су* [*Нурулланның*] *арыганлыгын бераз киметкән иде.* А. Шамов.

КИМЛЕК *и.* **1.** Ким (1 мәгъ.) булу хәле, сыйфаты.

2. *к.* кимчелек. *Аяк-кулым бөтен бөтенең, Буйсынның да сизмим кимлеген.* М. Җәлил. *Күңелеңне* [*яраткан кешеңнән дә*] *яхшы кеше юклыгына ышандырсаң, һичнинди кимлек тоймыйсың.* Ф. Яруллин.

3. *күч.* Түбәнлек, хурлык. *Алма үч, тәңре, Кабилдән, Үч алу кимлек сиңа.* Һ. Такташ.

Кимлек дәрәҗәсе *лингв.* — предметтагы берәр билгенең гади дәрәҗәдәгедән кимрәк булуын белдерә торган асыл сыйфатлар формасы.

КИМОҤГРАФ *и.* **1.** *мед.* Организмдагы процессларны теркәп бара торган прибор (мәсәлән, кан басымын, мускуллар кыскаруын һ. б.). *Профессор Янковский кимограф күрсәтмәләрен җентекләп күзәтә.* Соц. Тат.

2. Эксперименталь фонетикада авазларның әйтелешен язу приборы.

КИМОНО *и.* **1.** Японнарның киң җиңле, халат сыман милли өс киеме.

2. *махс.* Хатын-кыз күлмәгенең аерым бер фасон белән киселгән җиңе.

КИМСЕНҮ *ф.* **1.** Үзеңне башкалардан ким күрү, начар дип уйлау. *Малайларның русча белү өстенлеге Габдуллада кызыгу, көнләү тойгысы белән бергә, кимсенү тойгысы да тудырды.* Ә. Фәйзи. *Шулай да үзебезнең көтүгә куарлык кәҗәбез дә булмауга кеше арасында кимсенә торган идек.* М. Гали.

2. Кем тарафыннан булса да кимсетелгән дип уйлау, мыскылланган дип уйлау; хурлану. *Эчкерсез ягымлы сүзләрне ишетүгә, Зиннәт бөтен кимсенүләрен, барлык борчылуларын онытты.* Г. Бәширов. [*Кыз*] *әткәсенең соңгы сүзенә бик нык кимсенде булырга кирәк.* Ш. Камал.

КИМСЕНҮЛЕ *с.* Кимсенү чагылган, гарьләнүле (йөз, тавыш һ. б.).

КИМСЕТЕЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к. кимсетү* 1.

2. Мыскыл ителү, читкә кагылу. *Кечкенәдән үги ана кулында үскәнлектән, кагылуның, кимсетелеп яшәүнең нәрсә икәнен белә иде Гөлсем апа.* Г. Гобәй. *Син үзең дә бит миңа яшь чагында күргән кимсетелүләрең - - - турында сөйли идең.* А. Расих.

КИМСЕТҮ *ф.* 1. Ким күрү, җәберләү, санга санамау. [*Үги ана:*] *Менә, Зөһрә, сине үги кызым дип бер дә генә кимсетмим бит мин.* А. Әхмәт. — *Син юкка гына кимсетәсең дөньяне, Гөлсинә.* Р. Ишморат. *Юк бездә һичкемне кимсетү, Бар җирдә һәр кеше бертигез.* Ә. Исхак.

2. Кемне дә булса мыскыллау, хурлау, яманлау. [*Сафин*] *һәрбер тиешле-тиешсез урында Мохтарны мыскыллап, кимсетеп теңкәсенә тияргә тырыша иде.* Ш. Камал. *Безнең бабай тирәсендә үзара сугышу, бәйләнешү, бер-береңне кимсетү, хурлау кая инде ул?* Г. Гали.

КИМСЕТҮЛЕ *с.* Кимсетеп, түбәнсетеп карый торган. *Кимсетүле караш. Кимсетүле сүз.* | *рәв. мәгъ. Кыз кимсетүле итеп: — Әллә ишетмисеңме, скорый [пароход] иче: җиле белән дә капландыра ул сине.* Г. Гобәй.

КИМ-ХУР: **ким-хур булу** — 1) башкаларга караганда начар, түбәнрәк хәлдә булу, яшәү; [*Йөзлебикә Нәфисәгә:*] *Шушы буең-сыныңшушы укымышың белән, кайчан да ким-хур була торган бала түгел лабаса!* Г. Бәширов; 2) оятка, хурлыкка калу. [*Җәмилә*] *бөтен нәрсәне кеше арасында „ким-хур булмау, йөз кызартмау“ өчен эшли.* М. Гали. **Ким-хур итү** — мыскыллау, мәсхәрәләү, кимсетү. [*Дәүләтьяров:*] *Үзебезне ким-хур итәргә юл куймабыз.* И. Гази.

КИМЧЕЛЕК *и.* 1. Җитешсез як, җитешсезлек. *Тәҗрибәле карт офицерның үткен күзләре сафтагыларда бер генә кимчелек тапмады.* Г. Минский.

2. Зарар, зыян (берәр эштә, берәр нәрсәдә). [*Искәндәр:*] *Шәрәф улым, яхшы йөр. Бу якны күп кайгыртма. Укуыңа кимчелеге килер.* М. Фәйзи. [*Госман*] *үз эшенә һич тә кимчелек китермичә,* [*врач чакыртуны*] *бик уңай башкара алган булыр иде.* А. Шамов.

3. *күч.* Мохтаҗлык, авырлык, җитмәүчелек. *Кимчелек күрми яшәү.*

КИМЧЕЛЕКЛЕ *с.* Кимчелеге булган, җитешсезлеге булган. [*Рифгать*] *инптәшенең кимчелекле яклары турында бөтенләй диярлек телгә дә алмады.* М. Әмир.

КИМҮ *ф.* 1. Күләм, сан, зурлык ягыннан азаю, кечерәю. *Салам башлы өйләр кимегән.* Ә. Ерикәй. *Ындырның бер башыннан икенче башына тезелеп - - - торган биек кибәннәр кими баралар.* Г. Ибраһимов.

2. Көче, дәрәҗәсе, киеренкелеге һ. б. ягыннан кимрәк булып калу. *Әкренләп ыгы-зыгы кимеде, мотор авазлары да тына башлагандай булды.* М. Хәсәнов. *Йөрәгемдә ялкын арта, Бер дә кимеми иде.* М. Җәлил.

3. Сыйфаты, әһәмиятлелеге, тоткан урыны буенча түбәнәю, кечерәю (эшчәнлеге, кыйммәт һ. б.). *Октябрьдан соң Г. Камалның изҗат эшчәнлеге кимәде, киресенчә, көчәйде генә.* М. Гали.

4. Үзеңнең авырлыгыңны югалту, ябыгу. [*Камил:*] *Өч көн эчендә биш кадак кимедем.* Һ. Такташ.

КИНАЯ *и.* 1. Читләтеп әйтелгән сүз; аллегория. *Әлбәттә, Ифрат балалары алдында барын да сөйләми, күбрәк төрле кинаяләр аша гына хәлне аңлата иде.* А. Расих. *Гүзәл хатның әйтелеп бетмәгән урыннарын, кинаяләрен дөрес аңлады.* Г. Гобәй.

2. Нинди дә булса фактка ишарә; ирония. [*Сафа:*] *Җамали абзый ул әнә тимер-томырын да ала, куянмуянын да. (Киная белән.) Барысына да өлгерә.* А. Әхмәт. *Рамазанова - - - киная белән өстәп куйды: — Я, сменага соңга калмадыгызмы?* Г. Минский.

КИНАЯЛЕ *с.* 1. Читләтеп әйтелгән, читләтеп сөйләнгән; аллегорик.

2. Нинди дә булса фактка ишарәләп әйтелгән; иронияле. *Сарыбай бераз кинаяле мәгънә белән әйтә куйды: — Бай үлде, сиңа тун белән чапан калды, күңелең һаман канәгать түгелме?* Г. Ибраһимов. *Әлфиянең кинаяле сүзләреннән соң, ул* [*Газинур*] *шунда ук Миңнурый янына кермәкче иде.* Г. Әпсәләмов.

КИНАЯЛӘҮ *ф.* 1. Читләтеп сөйләү, нәрсәгәдер ишарә итү. [*Кәбир*] *Адаев белән төнәгән төзелештә очраштылар. Анда нидер кинаяләп маташты, бүген монда азапландыра.* А. Гыйләҗев.

2. *рәв. мәгъ.* **кинаяләп.** Турыдан-туры түгел, читләтеп. [*Габделхәй*] *кинаяләп сөйләргә ярата.* Ш. Камал. *Ширкин кинаяләп Инженерның уен кузгатты: — Тәгәрмәче ватык өчен генә Паровозны туздырмыйлар иче.* Ф. Кәрим. || Ирония белән, төрттереп. *Гарифулла кинаяләп әйтеп куйды: — Без икенче төрлерәк кунак көткән идек шул.* Г. Минский.

КИНГСТОН *и. махс.* Корабльнең су асты өлешендә судно эченә су кертә торган клапан. *Озак эзли торгач, хыянәтче капитанны машина бүлегендә, пароходны батырырга телән, кингстонны ачып маташкан җиренда таптык.* С. Сабиров.

КИНДЕР *и.* 1. Сабагыннан сүс, пәҗе, орлыгыннан май алына торган берьеллык үлән үсемлек. *Кыргый киндер. Киндер йолкы.* □ *Инде колхоз басуларында көнбагыш, киндер һәм җитен кебек соң өлгерә торган культуралар да чәчелеп бетте.* Г. Галиев. *Киндер комбайннары бит болар. - - - Менә монысы киндерне ура да, көлтәгә дә бәйли.* Сов. әд. || Шул үсемлекнең орлыгы. *Күгәрченнәр киндер чүпли ишек алды чирәмдә.* Җыр.

2. Шул үсемлек яки җитен сүсеннән эшләнгән тукыма. *Киндер сугу.* □ *Бәйрәм алдында әнисе нечкә киндердән күлмәкләр кисте.* Дәрдмәнд. *Искәндәр, чемоданын ачып, ак киндергә төрелгән берничә рәсем чыгарды.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Киндер алъяпкыч. Киндер капчык. Киндер күлмәк. Киндер сөлге.* □ *Мостафа маңгай тирләрен киндер бияләенең аркасы белән сөртеп җибәрде.* Ш. Камал. || Рәсем төшерү өчен кулланыла торган, шундый тукыма кисәге. *Каршыдагы стенага матур кысалы Репин рәсеме һәм астарак аның „Бурлаклар“ының киндергә төшерелгән яхшы күчермәсе эленгән.* Г. Бәширов.

Киндер мае — киндер орлыгыннан сыгып алына торган үсемлек мае. [*Солдатларга*] *яшел киндер мае салган борчак боткасы бирделәр.* М. Гали. **Киндер станы** — кул белән киндер сугу станогы. *Буй җиткән кызлар, сәке асты ачып, киндер станнары корып җибәрделәр, - - - киндер сугарга керештеләр.* Ф. Хөсни. **Киндер тукмаклау** *этн.* — яңа сугылган киндерне махсус тукмаклар белән кагып-сугып йомшарту (бу эш гадәттә яшь кызлар тарафыннан, өмә тәртибендә, җыр, уен-көлке белән башкарылган). — *Һи, бу кызларны да әйтер идем шул, үзләре киндер тукмаклый-быз дип йөргән булалар, - - - ә үзләре таганнарын да асып, әзерләп куймаганнар.* Г. Камал. **Киндер чыпчыгы** — тау чыпчыклары семьялыгыннан кечкенә сайрар кош; *русчасы:* коноплянка.

КИНДЕРАШ *и.* 1. *диал. к.* киндер 1.

2. Киндер орлыгы. *Киндерештан үсемлек сөте эшләү.* □ *Киндердән киндер дә була, киндераш та була.* Мәкаль.

КИНДЕРЧЕЛЕК *и.* Авыл хуҗалыгының киндер үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Колхоз кин-*

дерчелектән ел саен миллион сум чамасы доход ала. Г. Галиев.

КИНДЕРӘ *и.* Ишелгән нечкә бау. *Чабата киндерәсе.* □ *Мин мунчаладан бик әйбәтләп киндерә ишеп алдым.* А. Алиш. *Фатыйма улының билендәге киндерәсен чишеп алды.* И. Гази.

КИНЕМА'ТИКА *и. физ.* Механиканың җисемнәр хәрәкәтен геометрик яктан гына, ягъни хәрәкәтне тасвирлаучы ысулларны гына өйрәнә торган бүлеге.

КИНЕМАТО'ГРАФ *и. махс.* 1. Яктылык сизүчәнлеге көчле булган пленкага хәрәкәттәге объектларны төшерә, шулай ук аларны экранда күрсәтә торган аппарат. *Кинематограф лентасына алу өчен сценарий язучыларның ярышы игълан ителә.* Каз. утл.

2. *к.* кинематография 1.

3. *иск. к.* кинотеатр. *Шәһәр бакчасында - - - Кәримовларның „Йолдыз" исемендә кинематографлары бар.* Г. Тукай. [*Зыя*] *музыка хөрмәте өчен рус кинематографларына, бара-бара концертларга да йөри башлады.* Г. Ибраһимов.

КИНЕМАТОГРА'ФИК *с.* Кинематографка, кинематографиягә мөнәсәбәтле. *Кинематографик лента. Кинематографик сурәт.* □ *Аста вагон тәгәрмәчләренең бик тиз әйләнгәне ишетелә, тәрәзә алдыннан кинематографик кызулык белән кырлар, таулар ялтырап үтеп тора.* Ш. Усманов.

КИНЕМАТОГРАФИСТ *и.* Кинематография белгече, шул өлкәдә эшләүче. *Кинематографистлар киңәшмәсе.*

КИНЕМАТОГРА'ФИЯ *и.* 1. Махсус аппарат ярдәмендә төшереп алынган сурәтләрне экранда яңадан күрсәтү аша җанлы чынбарлыкны чагылдыру сәнгате; кино сәнгате. *Хәзерге кинематография проблемалары.* □ *Әдәбият һәм музыка кебек сәнгать төрләренең тарихы гасырлар белән исәпләнсә, кинематографиянекен исә дистә еллар белән генә санарга туры килә.* Н. Юзиев.

2. Культура һәм халык хуҗалыгының кинофильмнар чыгару һәм аларны тамашачыларга күрсәтү белән шөгыльләнә торган тармагы, бүлеге. *Кинематография промышленности. РСФСР Министрлар Советының кинематография буенча дәүләт комитеты.*

КИНЕСКОП *и. физ.* Телевизорда сурәт хасил итү өчен кулланыла торган электрон-нурлы көпшә. *Телевизорның яхшы эшләве кинескопка бәйле булу.*

КИНЕ'ТИК *с. физ.* Җисемнәрнең хәрәкәт итүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Кинетик энергия.* □ *Үзәк лабораториядә байтак кына матдәләрнең термохимик процесста кинетик үзгәрешен сыйфатлаган мәгълүматлар алынган иде.* Э. Касыймов.

КИНЕ'ТИКА *и. физ.* Теоретик механиканың динамиканы һәм статистиканы эченә алган төп бүлеге.

КИНЖАЛ *и. сөйл. к.* хәнҗәр. *Гайнулла разведчикларда була торган кинжалның очы белән ашыкмый гына төенчекне сүтәргә тотынды.* А. Әхмәт. *Кинжал — авызда, кобурам чишелгән, пычрак өстеннән үрмәлим.* И. Гази.

КИНО *и.* 1. *к.* кинематография 1. [*Горькийның*] *янына үтеп керә алмаслык. Бөтен тирә-ягын хәбәрчеләр, фотографлар, кино кешеләре әйләндереп алган. Г. Бәширов.*

2. *сөйл. к.* кинофильм. *Кичә клубта кино күрсәткәннәр.* Г. Әпсәләмов.

3. *сөйл. к.* кинотеатр. *Театр, кино һәм клуб залларында утлар күптән сүнделәр.* Г. Минский.

Кино аппараты — *к.* киноаппарат. — *Клубка тавышлы кино аппараты да алып куярга ниятләп торабыз.* Ә. Еники.

КИНО- Кушма сүзләрдә „кино", „кинематографик" мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: **кинокадр, киногазета, кинотамашачы, кинохикәя, киночелтәр, киноартист, киноэкран, кинокамера.**

КИНОАКТЁР *и.* Кинофильмнарда уйнаучы артист.

КИНОАКТРИ'СА *и.* Кинофильмнарда уйнаучы артистка. *Зәйтүнәдә бик бәләкәй чактан мине гашыйк иткән киноактриса сыйфатлары бар.* Б. Камалов.

КИНОАППАРАТ *и.* Кинофильмнар төшерү һәм аларны күрсәтү аппараты.

КИНОАППАРАТУ'РА *җый. и.* Кинематографиядә кулланыла торган төрле (төшерә торган, проекцион, тавыш язгыч һ. б.) аппаратлар, машиналар, станоклар.

КИНОАТЕЛЬЕ *и.* Кинофильмнар төшерү өчен җиһазландырылган махсус бина.

КИ'НОВАРЬ *и.* 1. Күкертле терекөмеш, кызыл төстәге минерал. *Киноварь ятмалары.*

2. *хим.* Күкертле терекөмештән алынган минераль кызыл буяу.

КИНОДРАМАТУРГИ'Я *и.* Кинематография чаралары белән сурәтләп күрсәтү өчен язылган әдәби әсәрләр жанры.

КИНОЖУРНАЛ *и.* Агымдагы тормыш вакыйгаларын чагылдырган аерым эпизодлар, сценаларны эченә алган кыска метражлы кинофильм. *Еш кына занятиеләрдә авыл хуҗалыгына багышланган киножурналлар күрсәтелде.* М. Хәсәнов.

КИНОКАРТИ'НА *и. к.* кинофильм. *Мин* [*Низамыйга*] *соңгы көннәрдә үзем күргән кинокартиналар турында сөйли башладым.* М. Әмир.

КИНОКОМЕ'ДИЯ *и.* Кино сәнгатенең бер жанры; мәзәк эчтәлекле кинофильм. *„Волга-Волга" кинокомедиясе.*

КИНОЛАШТЫРУ *ф.* Кайда да булса кинотеатрлар, күчмә кинолар оештыру. *Авылларны кинолаштыру.*

КИНОЛЕ'НТА *и.* 1. Кинофильмның аерым экземпляры (күчерелмәсе).

2. *сөйл.* Кинопленка. [*Казахстан далаларындагы*] *кешеләрнең барысын да кинога төшерә башласаң, киноленталар җитмәс! —* [*дип уйлап куйды Нурия*]. Г. Әпсәләмов.

КИНОМЕХА'НИК *и.* Кинофильмнар күрсәтү эшен башкаручы механик. *Киномеханик аппарат янына килүгә, мәктәп балалары, берәм-берәм шунда җыелып, аның лента корганын күзәтә башладылар.* А. Тимергалин.

КИНОМЕХАНИКЛЫК *и.* Киномеханик' һөнәре. *Укучыларны киномеханиклыкка өйрәтү түгәрәге.*

КИНООПЕРА'ТОР *и.* Кинога төшерү эшен туры-дан-туры башкаручы белгеч.

КИНОПЛЁНКА *и.* Кинематографиядә кинокартинаны төшерү яки бастыру өчен кулланыла торган яктылык сизүчән плёнка. *Казан кинопленка фабрикасы.*

КИНОПРОКАТ *и.* Экраннарда күрсәтү өчен кинофильмнарны күбәйтеп бастыру һәм аларны вакытлыча файдалану өчен кинотеатрларга, клубларга һ. б. биреп тору.

КИНОРЕЖИССЁР *и.* Фильмны куючы, кинокартина режиссёры.

КИНОСТУ'ДИЯ *и.* Кинофильмнар төшереп чыгара торган предприятие (кинофильм чыгару эшенең барлык — киносценарий иҗат итүдән башлап фильмның күчермәсенә кадәр — процесслары шунда башкарыла). *„Мосфильм" киностудиясе. Һәвәскәрләр киностудиясе.*

КИНОСЦЕНА'РИЙ *и.* Кинофильм чыгаруга нигез итеп алына торган әдәби әсәр. [*Ш. Усмановның*] *кульязмалары арасында тәмамланмаган романы да, дистәләрчә яңа хикәяләре дә, киносценарие да булган.* А. Яхин.

КИНОТЕАТР *и.* Халыкка кинофильмнар күрсәтү өчен махсус җиһазландырылган җәмәгать бинасы. *Бүген кинотеатрда „Полк улы“ исемле картина бара.* А. Әхмәт.

КИНОФЕСТИВАЛЬ *и.* Кино сәнгате әсәрләренең смотры, ижади ярышы (иң яхшы кинофильмнарны билгеләү, кинематографиянең үсеш тенденцияләрен ачыклау, төрле ил кинематографистлары арасында хезмәттәшлек булдыру, тәжрибә уртаклашу максаты белән үткәрелә). *Халыкара кинофестиваль үткәрү.*

КИНОФИКА'ЦИЯ *и.* Кинотеатрлар оештыру, нинди дә булса районда, урында киночелтәр булдыру эше.

КИНОФИКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Кинофикация үткәрү. *Барлык урта һәм сигезьеллык мәктәпләр кинофикацияләндә.* Каз. утл.

КИНОФИЛЬМ *и.* Экранда күрсәтү өчен эшләнгән кинематография әсәре. *Төсле нәфис кинофильм. Фәнни-популяр кинофильм.* □ *[Мәскәү хәзер] Гөлсем апа күреп белгән, кинофильмнар, рәсемнәр аша таныш булган сугышка кадәрге Мәскәү түгел иде.* Г. Гобәй.

КИНОЧЕЛТӘР *и.* Берәр төбәктә яки илдә кинотеатрлар, кино күрсәтү өчен җиһазландырылган урыннар җыелмасы.

КИНӘ *и.* Яшертен дошманлык; ачу, үч. *Әгәр дусларым вә юлдашларым күп булсын дисәң, кинә тотма.* К. Насыйри. *Заһид бу кинә саклаучан кыздан читтәрәк булырга теләде.* А. Расих. *Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар, Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.* Дәрдмәнд.

КИНӘЛЕ *с. к.* кинәчел. *Бик бәхетсез хатын икән ул Татьяна: бәхетле кеше ул кадәр кинәле булмый, ачуы нигезле булса да, кичерүчән була.* С. Баттал. *Кинәле кеше — әнәле кеше.* Мәкаль.

КИНӘНДЕРҮ *ф.* Куандыру, шатландыру. *Нәфисә белән бергә яши башлаганнан соң кичерәчәк рәхәтләр, бере артыннан бере күз алдына килеп, аны кинәндерә иде.* Г. Бәширов. — *Мәрфуга килен эшләп кинәндерми, көе килгәндә бик әйбәтләп булышкалый, --- бер нәрсә ярамаса, үпкәләп, әче телләнә башлый.* Г. Ибраһимов. || Берәр нәрсәгә булган зур ихтыяҗны канәгатьләндерү. *„Рәхмәт! Рәхмәт [Советка]! Кинәндерделәр җиргә!“ — дип сөйләнде [Гафият].* И. Гази.

КИНӘНЕЧ *и. сир.* Шатлык, куаныч, сөенеч; ләззәт. — *Минем бөтен рәхәтем, бөтен шатлыгым, бөтен кинәнечем син, синең хакыңда уйлау.* К. Тинчурин.

КИНӘНҮ *ф.* Куану, шатлану. *Киң басуларга карыйм да, Күңелем кинәнеп куя.* Ә. Еникәй. *Җаббар абзый --- хәлсез генә, ләкин бик кинәнеп көлеп җибәрде.* Ә. Фәйзи. || Рәхәтләнү, тулы рухи канәгатьлек алу. *Җәен үрдәк күп була монда. Д кышын куян аулап кинәнәбез.* А. Расих. *Әмма шунысы шәп: кинәндем ат өстендә йөреп.* Ф. Хөсни.

КИ'НӘТ *рәв.* Һич көтмәгәндә, искәрмәстән, кисәктән, капыл. *Кинәт баеган кешегә күрше йорты кетәк булып күренә, ди.* Мәкаль. *Яз көне иде, кич иде, кинәт әллә ни булды: өйдә елаша башладылар, ыгы-зыгы купты.* Г. Бәширов. *Атыш ничектер кинәт башланды һәм берьюлы көчәгә китте.* Г. Әпсәләмов. || Кискен, текә. *Агыйдел, безнең ындыр турында кинәт бер борма ясап, авылның эченә кереп язып кала.* Г. Ибраһимов. || Берьюлы, шунда ук. *Шау-шу кинәт тынып калу.* □ — *Андый-мондый бәхетсезлек вакыйгалары булганда, эшчеләрнең ачулары кинәт кабынып китә торган була.* Ш. Камал.

КИНӘТЛЕК *и.* **1.** Кинәт булу хәле. *Бу көтелмәгән сүзләр һәм мондый кинәтлек тирә-яктагыларга башта сәер тоелып китте.* К. Басыйров. *Губернатор ничек бердән шаяруга күчкән булса, шундый ук кинәтлектә яңадан җитди хәленә кайтты.* Г. Минский.

2. Дуамаллык, ашыгып эш итүчәнлек. — *Чынлап бик яхшы кеше ул безнең Шамин. Кинәтлеге бар барын.* А. Гыйләҗев.

КИ'НӘТТӘН *рәв. сөйл. к.* кинәт. *Бервакыт кинәттән сискәнеп уянам.* Ш. Бабич.

КИНӘЧЕЛ *с.* Кинә тотучан. *Яман кеше—кинәчел.* Мәкаль.

КИОСК *и.* Газета-журнал, китап, чәчәк һ. б. ш. әйберләр сату өчен зур булмаган махсус корылма. *Нәкъ шул вакыт киоск янына бер хатын килеп басты, ул да газета сорады.* А. Шамов. *Су киоскларына баш тыгарлык хәл юк: һәр җирдә халык шыгрым тулган.* И. Гази.

КИОСКЫЧЫ *и.* Киоскта сату итүче. *Мәдинә Шәмсетдинова кебек киоскычылар күбрәк булсын иде.* Соц. Тат.

КИП *и. сөйл.* **1.** Берсе өстенә икенчесен салып урнаштырылган бериш әйберләр бәйләме, төргәге. *Кәгазь киплары.* □ *Төнге вагон. Йокылы керфекләр. Чемоданнар. Киплар. Баулар.* Ә. Ерикәй.

2. Кайбер товарларны төрүдә кулланыла торган күләм-зурлык үлчәве; бәйләм, төргәк. *Мин кооператив исеменә дип 15 кенә кип кызыл мал алган идем.* К. Әмири. *Ел саен Мәскәрҗәдән, Мәскәүдән йөзләп, ике йөзләп кип товар килә башлады.* Ш. Мөхәммәдев.

КИП-КИҢ *с. Артык. дәр. к.* киң. *Ул чыгарган ташны җиргә җәйсәң, Күплегеннән кип-киң кыр булыр.* М. Гафури.

КИПАРИС *и.* Көньякта үсә торган, күпчелек пирамидаль ябалдашлы, мәңге яшел ылыслы агач. *Сузылып үскән зифа кипарислар Чолганалар куе томанга.* Ә. Ерикәй. — *Д Зөфәр белән Миңзифа Кырымга китәләр. Кара диңгез буйлары, кипарис күләгәләре кочагына!* Ш. Камал.

КИПТЕРГЕЧ *и.* Язу карасын үзенә сеңдерә, киптерә торган махсус кәгазь. *[Әхмәди] бер сүз дә әйтмәде, киптергечен кулында бөтәрли-бөтәрли тик торды.* Г. Мөхәммәтшин. *Өстәл өстенә кызыл киптергеч кәгазь дә җәйгәннәр: кара савытларына кара да салып куйганнар.* Ак юл.

КИПТЕРҮ *ф.* **1.** Коры хәлгә китерү (нинди дә булса юеш, дымлы әйберләрне). *Ак кулъяулык элеп куям җилгә, Җил тибрәтеп аны киптерә.* Ф. Кәрим. *Орлыкларны бер савыттан Бер савытка тутыра, Әле суда чылата да, әле җәя, киптерә.* М. Җәлил. *Кояш кичә явып киткән яңгырның калдырган ахыргы юешлекләрен дә инде киптереп бетерә башлаган.* Ф. Әмирхан. || Суын нинди дә булса юл белән агызып, саркытып корыту, коры урынга әйләндерү. *Сазлыкны киптерү.* □ *Шәвәли абзаң шушы бакча урынын сазламыктан тартып алганчы ике ел чиләнде. Ермаклар ерып, суын агызды, җирен киптерде.* Г. Ахунов. || Кирәкле дымнан мәхрүм итеп, артык дәрәҗәдә корыту. *[Уральск шәһәрен] Азия үзенең кайнар сахра җилләре белән киптереп ташлый, ком бураннары күтәрә.* Ә. Фәйзи. || Сөртеп яки нәрсәгә дә булса сеңдереп корыту. *Киптергеч белән киптерү.*

2. Озак саклау өчен махсус хәзерләнә торган үсемлек, җиләк-җимеш, балыкның һ. б. дымын, юешлеген бетерү. *Шомырт киптерү. Гөмбә киптерү.* □ *Вәли, --- хәтыннар белән бергә, тозланган, җепкә тезелгән балыкны элеп йөри, киптерә.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Хәлимә әлеге куакларның кызыл яфракларын җыя да, кояшта киптереп, шуннан чәй ясый икән.* Д. Аппакова.

3. *күч.* Төрле җәберләүләр, рухи газаплаулар белән йончытып, интектереп ябыктыру, авыру хәлгә җиткерү (кешегә карата). [*Әминә Саттарга:*] *Мин кипмәгән идем, син мине киптердең. --- Мин чәчәк төсле идем, гомерем буенча син мине елан төсле суырып килдең.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Егетләрдән егетләр һич ким түгел, Безне дөнья сагышы киптерә.* Җыр.

КИПШЕНҮ *ф.* **1.** Кибү, кору; сурыгу. *Ул, мылтыгын саргаеп кипшенә башлаган үләнгә куеп, су читенә килде.* Мәр. Рафиков. *Сабираның күзләре чытырдап йомылган, кипшенгән иреннәре ачылган.* Ә. Фәйзи. *Лапас асты да, абзар-кура әчләре дә сазлыкка әйләнгән, алар тиз генә кипшенерлек түгел.* Г. Галиев. || Тамак кибү, сусау турында. — *Эссе, тамагыгыз кипшенгән бугай.* Н. Дәүли.

2. Ябыгу, корышу.— *Җәдитләр! — дип куйды карт, зәп-зәңгәр кан тамырлары бүртеп торган, кипшенгән кулын селтәп.* А. Расих.

КИПШЕРТҮ *ф. з-сыз.* Киптерү, корыту турында. *Җәй—җәй инде ул: явым-төшемнән соң тиз җилли, тиз кипшертә.* С. Рафиков.

КИПШЕРҮ *ф.* **1.** *к.* кипшенү 1. *Иреннәр кипшерү.* □ *Язгы сулар һаман кипшереп бетмәгән.* Ш. Маннур. *Кипшерергә дип, салкын мич алдына оеклар, юеш күлмәкләр (элеп куелган).* А. Гыйләҗев. *Тыштан ачык тәрәзә аша --- яшь үлән исе, кипшергән туфрак исе килеп керде.* Г. Ахунов.

2. *күч.* Ябыгу, корышу. *Шушы кипшереп как сөякка калган, тавышы да хәлсез генә булып чыга торган карт кайчандыр аю тоткан.* Н. Исәнбәт.

КИПШЕТҮ *ф. к.* киптерү **1.** *Гөблә тиресе шундый да юка бернәрсә: аның аркылы су да бик тиз очучан, гөбләне кипшетеп тә куючан.* Г. Хәсәнов.

КИПШҮ *ф. к.* кипшенү. *Аякларыбыз астында кипшегән такталар, дөпе-дөпе килеп, күңелле генә шаулашып калалар.* М. Хәсәнов. — *Ул бит мине ярата, ярата, Илдархан абый. Белмисез генә, минсез саргаеп, кипшеп бетә ул.* Н. Исәнбәт.

КИРАСА *и.* **1.** Элекке заманда чәнчә һәм чаба торган сугыш коралларыннан күкрәк һәм арканы саклау өчен металл кием.

2. Көнбатыш Европа һәм 1917 елга кадәр рус армияләрендә кайбер гвардия полкларының парад формасы.

КИРАСИР *и.* **1.** Атлы армиядә кираса (1 мәгъ.) кигән җайдак.

2. Көнбатыш Европа һәм 1917 елга кадәр рус армияләрендә кайбер кавалерия полкларында хезмәт итүче солдат яки офицер (парадка чыкканда кираса кигәнгә шулай аталган). || *с. мәгъ.* Шундый гаскәриләрдән торган. *Кирасир полклары.*

КИРЕ *с.* **1.** Элекке хәрәкәткә капма-каршы булган. *Кире юнәлеш алу. Кире йөреш.* □ *Абдул --- Урмановны кулыннан алды да, акрын атлап, кире якка таба алып китте.* Г. Ибраһимов. || *рәв. мәгъ.* Элекке хәрәкәткә капма-каршы якка. *Кире чигенү.* □ *Шәйхаттар белән Хәлим, кызларга күренмәс өчен, агачларга ышыклана-ышыклана кире киттеләр.* Г. Гобәй. *Куян, рәшәткә арасыннан үтә алмаганга, кире борылган.* А. Алиш.

2. Тискәре, эчке (кием турында). *Күлмәкне кире ягына кию.*

3. Нәрсәне дә булса хупламый, кирәклеген, әһәмиятен танымый, инкяр итә торган. *Кире караш. Кире мөнәсәбәт. Кире бәя бирү.* □ *Әпипәнең җыелыш саен --- берәр кире сүз әйтмичә күңеле тынмый иде.* Г. Бәширов. [*Мортазин*] *һәрнәрсәнең кире ягын гына күрә башлады.* Г. Әпсәләмов. || Тискәре, начар. — *Тәртипкә чакырырга кирәк андый кешеләрне. Башкаларга кире йогынты ясап куюлары бар.* С. Рафиков. || Начар, ямьсез, күңелсез. *Кире тәэсир калдыру.* □ *Әй шулай да кире уйлар һаман кыра йөрәкне.* М. Җәлил.

4. Берәр нәрсәнең юклыгын, уңай якка булмавын раслый торган; көткәнгә капма-каршы булган. *Зифа карчык аны [Шәрифулланы] табын янына, көндезге ашка чакырды, әмма кире җавап алды.* А. Шамов. — *Менә гел шулай: бер уңай нәтиҗә аласың, канатланып, шатланып йөрисең. Кисәк — кире нәтиҗә. Канатың каерыла.* Х. Вахит.

5. *күч.* Үзсүзле, тыңламаучан, үзенчә генә эшләргә яратучы, тискәре, үҗәт. *Паларусов урынсыз чигенүне белми торган кире адәм иде.* Г. Ибраһимов. — *Кире дигәндә дә, моннан [әхмәттән] артык бер кире булмас.* Г. Камал. *Карт юләр яшь юләрдән киререк була.* Мәкаль.

6. *әд.* Матур әдәбиятта: уңай геройларга каршы куелган, тискәре сыйфатлы. *Кире образ.* □ *Мәгъри белән Гайни әсәрдә бөтенләй кире типлар итеп күрсәтеләләр.* М. Гали.

7. *мат.* Берсенең артуы белән икенчесе кими торган (яки киресенчә). *Кире пропорциональ бәйләлек. Кире пропорциональ зурлыклар.*

8. *мат. к.* тискәре 8. *Кире саннар.*

9. *физ.* Материаль кисәкләре электроннан торган электр төренә бәйләнешле. *Кире корылма.*

10. *рәв. мәгъ.* Яңадан, кабат, тагын. *Бер кискән икмәк кире ябышмый.* Мәкаль. [*Галимә апа*] *шәленең бер почмагын һич туктаусыз төрә дә аны кире сүтә, тагын төрә, тагын сүтә иде.* М. Гафури. *Алдым тире, саттым кире.* Әйтем.

11. *бәйл. функ. сөйл.* Соң, ары. *Калган эш — төштән кире.* Мәкаль.

Кире адрес — хат, посылка, телеграмма җибәрүченең үз адресы. *Кире адрес: „Мәскәү“ дигән, Аннан язган урамын.* М. Җәлил. **Кире хәл** *лингв.* — җөмләдә ияртүче кисәктән аңлашылган процессның киресе булачагын белдерә торган иярчен кисәк. **Кире җөмлә** *лингв.* — иярченле кушма җөмләнең бер төре (баш җөмләдә әйтелгән фикернең киресен белдерә).

◇ **Кире (кайтарып) алу** — үз сүзеңнән, фикереңнән, тәкъдименнән баш тарту. [*Хан:*] *Китегез. Калдырыгыз киңәшләрегезне! Кире алмамын һич тә сүземне!* Ф. Бурнаш. [*Һөнәр мәктәбе мөдире*] *гаять каты күңелле кеше иде. Дөрес әйтәме, дөрес түгелме — бер әйткән сүзен һичбер вакыт кире кайтарып алмый.* Х. Садрый. **Кире баштан** — яңадан, өр яңадан. *Кире баштан эшләү.* **Кире башы белән** — астын өскә әйләндереп. *Бабай, кире башы белән тоткансың язуны, --- менә болай әйләндереп тот!* М. Гали. **Кире беткән** — тыңламаучан, үзсүзле, үҗәт. *Гата --- каты күңелле, үзсүзле, кире беткән кеше иде.* Г. Ибраһимов. **Кире бору** — кабул итмәү; үтенеч, сорауны канәгатьләндермәү турында. — *Без эш сорап килдек, аласызмы, кире борасызмы?* Г. Минский. *Әмма әнисе карчык [яучыларның] килгән берсен кире борып торды.* Г. Бәширов. **Кире кагу (сугу)**— 1) кабул итмәү, нәрсәдән дә булса баш тарту. *Ашны кире кагуга караганда таш белән ору артыграк.* Мәкаль. *Әптелбәр, бик уйнарга теләсә дә, бу тәкъдимне кире какты.* Ә. Фәйзи; 2) риза булмау, каршы килү. — *Яшьтән сөйгән үз танышың егет башы белән шулай өзелеп тора икән, әйдә, кире какма.* Г. Бәширов. **Кире кагылгысыз** — ышандырырлык, бәхәсләшергә урын калдырмаслык. *Академик М. И. Губкин бу ягулыкның [нефтьнең] органик юл белән килеп чыгуы турында кире кагылгысыз дәлилләр белән раслый.* Каз. утл. **Кире кайтмый торган җиргә китү** *эвф.* — үлү. *Ак киемләләрнең берсеннән сорадым: кая,*

мин әйтәм, безнең Иванов, дим. — Кире кайтмый торган җиргә китте, — ди. Г. Ибраһимов. **Кире кайтару** — 1) кабул итмәү, борып жибәрү; 2) *к.* кире (кайтарып) алу. *Кире кайтар, бәгърем, сүзләреңне, Яндырма син мине утыңда.* Ф. Бурнаш; 3) яңадан элекке хәлне, тәртипне торгызу, урнаштыру. *Капитализмны кире кайтарырга маташу;* 4) *экон.* нәрсә дә булса җитештерү өчен тотылган чыгымны каплау. *Продукциянең үзкыйммәтен кире кайтару;* 5) каршы һөҗүм белән җавап бирү. *Кызыл гаскәр беренче һөҗүмне кире кайтарды.* Ш. Усманов. **Кире кайту** — ниятне, фикерне үзгәртү; үз тәкъдимеңнән, корган планнан баш тарту. *Күңел китмәү ягын каерса да, Бер уйлагач, кире кайтмады.* М. Гафури. — *Акбуләк дус, биргән киңәшеңнән кире кайтма.* Р. Ишморат. **Кире килү** — 1) карышу, риза булмау. *Бу киңәшкә шүрәле дә көнде, килмичә кире.* Г. Тукай; 2) уңай, җай булмау, киресенчә булу, каршылык чыгып тору. *Безгә дигәндә гел кире килеп тора.* **Кире сөйләү** — каршы килү, кушылмау (кемнең дә булса фикеренә). **Кире китү** — *к.* киргә китү (1 *мәгъ*). *Җиңелне өмет иткән — Тормышы кире киткән.* Мәкаль. **Кире кырыккан** — *к.* кире беткән. *Айнукның гаять мактанчык, кире кырыккан бер кызы бар иде.* К. Тинчурин. **Кире уйлау** — уйлаганча, сөйләшкәнчә эшләмәскә булу, ниятне үзгәртү. — *Син бервакыт вәкаләт сатарга йөргән идең, кире уйладың, ахры.* Т. Гыйззәт. **Кире чөй кагу** — каршы килү яки киресен сөйләү. — *Мостафалар коммуна төзиләр. Әллә бергәләп керәбезме, кордаш? --- Ишмай, Халикъка кире чөй какмаган хәлдә, үзе нәрсәдер икеләнеп калды.* Ш. Камал. **Кире (як) юлга** — начарлыкка, ярамый торган эшкә. [*Вәли:*] *Сез мине кире як юлга тартырга телисез икән, аныңы булмас, бабай.* К. Әмири. *Театр яктылыкка— нурга илтә. Кире юлга җибәрми, уңга илтә.* Г. Тукай. **Кире ягы белән** — икенче төрле, бозып; начар, зарарлы ягын гына күрсәтеп. [*Гайбәтчеләр мәсьәләне*] *кире ягы белән аңлаталар.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Кире як белән тору** — кәефсез булу яки киреләнү, кирле-мырлы сөйләшү турында. — *Әй, Биктимер күрше, син бүген бөтенләй кире ягың белән торгансың, ахры.* А. Алиш. **Кире әйләнү** — киргә борылу, килгән юлдан кире китү. *Низамый безне күп озатмады, беренче тыкрыкны борылуга ук кире әйләнде.* М. Әмир.

КИРЕГӘ *рәв.* **1.** Артка, кире якка. *Киргә каерылу. Киргә бөгү. Киргә санау.* □ *Су анасы, куркып этләрдән, киргә йөгерә.* Г. Тукай. *Без атларга таба, киргә шуыштык.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Начар якка (үсеш, үзгәреш турында). — *Әсин, Җиһан, үзгәрдең. Ай-һай бик нык үзгәрдең. Яхшы якка түгел — киргә.* Г. Мөхәммәтшин. *Без яңага таба юл тотабыз. Сез — киргә таба.* Ә. Ерикәй.

◊ **Киргә алу (бору)** — 1) киресенчә, юри бозып аңлаган булып кылану; 2) ялгыштыру, буташтыру (эшне, фикерне һ. б.). **Киргә кагу** — хупламау, теләмәү. — *Әлбәттә, арада* [*бу эшне*] *киргә кагучылар да булды.* Ш. Камал. **Киргә китү** — 1) начарлану; начар якка таба үзгәрү; үсмәү, алга бармау. *Вәли абзыйның да кәсепләре киргә китте.* Ә. Фәйзи; 2) аң үсеше, политик яктан артта калу. *Искеләр* [*кадимчеләр*] *арасында көннән-көн яшьләргә карата реакция куәтләнә бара. Искеләр көннән-көн киргә китә баралар.* Ф. Әмирхан; 3) начарлану, көчәю (сәламәтлек, авыру турында). *Галимә апаның авыруы тагы да киргә китте.* М. Гафури. **Киргә сукалау (саплау, тырнау, бутау, җөпләү)** — киресенчә сөйләү, капма-каршы сөйләү; киресен исбатларга тырышу. *Кемгә нинди эш белән кагылма — һәммәсе киргә сукалый.* С. Рафиков. *Кире—киргә саплар.* Мәкаль. — *Миңъдат, син киргә җөпләмә, син эшнең ничек барасын бик яхшы беләсең бит.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Гаяз инде аны* [*Гыймадины*] *килеште дип йөргән иде. Ә ул һаман киргә тырнап маташа.* И. Гази. **Киргә әйләнү** — уйлаганча, теләгәнчә булмау. *Эшләр киргә әйләнү.* □ *Киргә әйләнде, дустым, кояшың.* Ф. Бурнаш.

КИРЕДӘН *рәв.* **1.** Яңадан, яңабаштан. *Яңгыр сулары юган сукмакта ис тоелмый башлагач, Актүш киредән будкага таба борылды.* Г. Гобәй.

2. Киргә, кире яктан. *Сүзне киредән уку.*

КИРЕЛЕК *и.* **1.** Үзсүзлелек, тискәрелек, үҗәтлек; тыңламаучанлык. *Патша һаман үзенең кирелегендә, горурлыгында дәвам итте.* К. Насыйри. — *Кирелек— акыллылык түгел.* Р. Ишморат.

2. *күч.* Көтелмәгән үзгәрешләр, уңайсызлыклар; тотрыксызлык; каприз. *Язның тискәрелегенә, җәйнең кирелегенә карамастан, борчак-баһадир бирешмәгән.* Сов. әд. *Бакыр тауның кирелекләреннән Нигъмәтҗан агай, авылның барлык кешеләре белән чагыштырганда, күбрәк җәфа күрде.* Г. Галиев.

◊ **Кирелеккә бару** — киреләнү, үзсүзлеләнү. *Минем Сәлим бабайның күрә торып шулхәтле кирелеккә баруына исем китте.* Н. Исәнбәт.

КИРЕЛЕ-МЫРЛЫ *рәв. к.* кирле-мырлы. *Кирелемырлы сөйләнеп килгәннән соң,* [*Сәлмән карт*] *кинәт серле рәвештә тынып калды.* Ф. Хөсни.

КИРЕЛЕ-СОҢЛЫ *рәв. диал.* **1.** Бер артка, бер алга, арлы-бирле. *Киреле-соңлы йөренү.* □ *Мостафа, винтовканы кулына алып, затворын киреле-соңлы тартып, сәкегә куйды. Ш. Камал.*

2. Тупас, тәртипсез, мәгънәсез итеп. *Исак барак ишеген ачты да аптыраган тавыш белән киреле-соңлы җикеренергә тотынды.* Ш. Камал.

КИРЕЛӘНҮ *ф.* Кирелек күрсәтү, карышу, риза булмау. *Фәрхетдин белән Тәгъзимәнең --- киреләнүләреннән курыкты ул.* А. Расих. — *Кара аны, балакай, болай киреләнсәң, мин ачуланырмын.* Г. Гобәй.

КИРЕЛӘҮ *ф. сөйл.* Фикерне, ниятне үзгәртү, алай эшләмәскә булу; кире уйлау. — *Ярый алайса, мин киттем, Габдулла. Вәгъдәдә бит инде? — Киреләгәнне көтәсеңме соң син, Балламетдин?* И. Нуруллин.

КИРЕСЕ *и.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса капма-каршысы. *Киресен исбатлау.* □ *Әлфия, Миңнурыйның киресе буларак, бик оялчан иде.* Г. Әпсәләмов. *Габделнасыйрның елавы озакка сузылмады. Кинәт аны елаткан теге хис бөтенләй киресенә әйләнде.* Ф. Әмирхан.

КИРЕСЕ!НЧӘ *рәв.* **1.** Бөтенләй башкача, нәрсәгә дә булса капма-каршы. *Киресенчә эшләү.* □ *Әтисе* [*Габделкаюмны*] *--- берәр кыш тагын русча укытырга уйлаган иде, ләкин эш киресенчә булып чыкты.* М. Гали. || Кемнең яки нәрсәнең дә булса капма-каршысы, киресе буларак. *Минем әти, Фәхри бабайның киресенчә, бик йомшак күңелле, юаш --- кеше иде.* М. Гафури. [*Мәрзия*] *бүген, гадәттәгенең киресенчә, Каюмны ачык йөз белән каршыламады.* Ш. Камал.

2. *кер. сүз функ.* Әйткәнгә, уйлаганга, көткәнгә капма-каршы буларак. — *Сез миңа чит түгел, киресенчә, бик якын тоглассыз.* М. Хөсәен. [*Фазыйл:*] *Син бит мине аңламадың, Сания. — Киресенчә, мин хәзер синең кемлегеңне бик яхшы аңладым.* Р. Ишморат.

КИРЗА *и.* Аяк киемнәре, базар сумкалары һ. б. әйберләр эшләүдә күнне алыштыра торган, махсус матдә сәндерелгән нык, тыгыз тукыма. || *с. мәгъ.* Шундый материалдан тегелгән. *Иңләп-буйлап үттек сугыш кырын Сары шинель, кирза итектән.* Г. Хуҗиев.

КИРКА *и.* Таш, боз һ. б. ш. каты токымнарны вату, ваклау, казу өчен агач сапка чүкеч сыман итеп утыртылган очлы озынча тимердән гыйбарәт эш коралы; кәйлә. *Боз тауларын тигезләргә кирәк. Менә шуның өчен безнең батырларның кулларында лом, кирка, көрәк.* А. Алиш.

КИРЛЕ-КӘРЛЕ *рәв. диал. к.* кирле-мырлы. [*Насрый*] *яткан җирендә дә байтак кына кирле-кәрле сүгенеп маташты.* Ш. Камал.

КИРЛЕ-МЫРЛЫ *рәв. сөйл.* **1.** Теләсә ничек, буталчык, мәгънәсез итеп. *Днисенең кирле-мырлы сөйләнүе, гел киребә алуы гажәпләндерде аны.* С. Рафиков.

2. Начар, рәтсез. *Һава шартларының кирле-мырлы булуын исәпкә алсак, бу уңыш начар түгел.* Сов. әд. — *Мин кирле-мырлы эшләргә яратмыйм.* Ә. Еники. || Тигезсез рәвештә, кыек-мыек. *Пычкы коры нарат кайрысын беркадәр кирле-мырлы тырнап торды да эз салып кисә башлады.* Г. Гобәй.

КИРПЕЧ *и.* **1.** Үзле балчыктан озынчык шакмак формасында яндырып эшләнгән һәм төзү материалы итеп кулланыла торган ясалма таш. *Кирпеч сугу. Яндырылган кирпеч.* □ *Бу авылдагы һәр йортның мичен ул* [*Шәрифулла*] *чыгарган, аның һәр кирпечен үз кулыннан үткәргән.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Кирпечтән салынган, эшләнгән. *Кирпеч стена. Кирпеч сарай.* || *с. мәгъ.* Кирпеч җитештерүгә бәйләнешле. *Төхфәт кирпеч заводыннан - - - күн заводына күчеп эшли башлады.* Ш. Камал.

2. Шундый формада эшләнгән төрле әйбер, материал. *Торф кирпечләре.* □ [*Сәйдә җиңги*] *хуҗалыкта булган кадәр мал-туарны карый, тирес басып, кыш ягып чыгу өчен кирпечен дә үзе суга.* С. Рафиков. || *с. мәгъ.* Шундый формадагы. *Кирпеч икмәк.*

3. *с. мәгъ. сөйл.* Уен картасында: кызыл ромблар төшерелгән. *Кирпеч туз. Кирпеч король.*

КИРПЕЧЛӘП *рәв.* Кирпеч формасында. *Кая карама, тау-тау итеп кирпечләп сугылган тизәк өеп куелган иде. Монысы дала халкының кышлык утыны иде.* Н. Фәттах.

КИРПЕЧЧЕ *и.* Кирпеч сугучы. *Игенчегә явым кирәк, кирпеччегә аяз кирәк.* Мәкаль.

КИРТ *и.* Агачка яки башка нәрсәгә үткен әйбер белән кисеп яки чабып ясалган эз, тамга; сыр. *Көтучеләрдә бер сыер — бер кирт, ике бозау — бер кирт, алты сарык бер кирт булыр.* Шура.

КИРТӘК *и.* Киртеп, уеп алынган урын; уенты. || *с. мәгъ.* Почмаклап киселгән, почмаклап уеп алынган. *Авылда яшьләр арасында җиңсез камзуллар, киртәк якалы казакилар кию модага кереп китте.* М. Гали.

КИРТӘКЛӘҮ *ф. к.* киртләү. — [*Бала-чага*] *тәрәзә төпләрен сынган очлы пәкеләр белән киртәкләп бетермиме дисең?* Ш. Камал.

КИРТЛӘҮ *и.* **1.** Гадәттә табигый рәвештә барлыкка килгән яки махсус (төзелеш, архитектура һ. б. ш. максатлар өчен) ясалган горизонталь яки авыш чыгынтылы мәйданчык; киртле-киртле, уентылы-уентылы өслек. *Тау киртләче.* □ *Егетләр, кыяның бер киртләченә менеп, шаулап аккан суны байтак вакыт күзәтеп тордылар.* А. Расих. [*Сөләйман*] *базның авызы турысында, югарыга менәр өчен, стенага аяк басып торырлык киртләчләр казырга кереште.* К. Тинчурин. *Орудие көпшәләреннән, Кремль стенасындагы киртләчләрне кызгылт шәүлә белән яктыртып, ут телләре гөлт-гөлт кабынудан туктамады.* К. Нәҗми. || *с. мәгъ.* Шундый мәйданчыгы, өслеге булган. *Киртләч таш койма.* □ *Урамнарга март җилләре килгәч, Киртләч карлар тавын бетерә.* Ш. Маннур.

2. Кайбер предметларның кырыендагы вак төшле чыгынты. *Тәрәзә йөзлеге киртләчләре.* □ *Киртләчкә эләккән кире чыкмас.* Мәкаль. || *с. мәгъ.* Шундый чыгынтылары булган; киртләчле. *Ак кәгазь өстендә — [Нәфисәнең] дустына җибәрер өчен түгәрәк аланнан алып кайткан киртләч кырыйлы имән яфрагы.* Г. Бәширов.

КИРТЛӘЧ-КИРТЛӘЧ *с.* Киртләчләнеп торган. *Агач коймалар буена җил-буран киртләч-киртләч кар көртләре өеп китте.* М. Галәү. || *рәв. мәгъ.* Күп киртләчләр (2 мәгъ.) ясап. *Киртләч-киртләч булып күтәрелгән биек кыя тау.* □ *Карлар яуган киртләч-киртләч, Киртләчләре бетәр яз җиткәч.* Җыр.

КИРТЛӘЧЛЕ *с.* Киртләчләре булган, киртләчләнеп торган. *Агач күләгәләре астында киртләчле каты балчык һәм вак ташларга кагыла-кагыла аккан елганың тоныклыкына гөрләгән тавышлары - - - ишетелә.* Ш. Камал.

КИРТЛӘЧЛӘНҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* киртләчләү. *Түрдә өстенә бер нәрсә дә җәелмәгән, - - - үткен пәкеләр белән киртләчләнгән, сырланган иске өстәл.* А. Шамов.

2. Киртләч хасил итү; киртләч-киртләч булып тору. *Тулы ай - - - алтын багана булып инеш төбенә сузылган. Багана вакыт-вакыт күз иярмәс тизлек белән дулкынлана, читләре киртләчләнә.* Г. Гобәй. *Уң* [*яктан*] *киртләчләнеп киткән ташлы яр буйлары күренә.* Г. Әпсәләмов.

КИРТЛӘЧЛӘҮ *ф.* Кирт, киртек яки киртләч ясау. *Мәктәп парталарын шушы пәкеләр юнып киртләчли иде инде.* Г. Ахунов. [*Прохор*] *әлеге таягының киртләчләп уеп алынган башын үзе ишкән бауның әлмәгенә киертеп куйды.* М. Әмир.

КИРТЛӘҮ *ф.* Кирт ясау; кирт ясап, уеп тамга салу. *Бүрәнә башын балта белән киртләп алу.* □ [*Бабай*] *чират башыннан кемдә ничә тапкыр ашаганны һәм алган көтү хакын - - - юкәгач таякка киртли бара.* М. Гали.

КИРТӘ *и.* **1.** Егып, ботакларыннан арындырылган юан булмаган озын агач кәүсәсе; колга. [*Өй*] *кыегы, ишек алды, тагын әллә нәрсәләре өчен егерме тәнкәлек төрле бүрәнәләр, киртәләр, такталар алдык.* Г. Ибраһимов. *Киртәләрдән генә корылган койма һәм җил капка аша йорт эче күренеп тора.* Каз. утл.

2. Өй, бакча, басу һ. б. әйләнәсендә шундый агач кәүсәләрен казык баганалар арасына буйга салып эшләнгән аралы койма. *Киртә тоту.* □ *Илгизәр, киртә арасыннан кысыла-кысыла кереп, этисе янына килде.* Г. Бәширов. *Скважина алды мәйданчыгы киртә белән әйләндереп алынган.* А. Әхмәт. || Сугыш кырында дошманның хәрәкәтен тоткарлау өчен чәнечкеле тимерчыбыклардан ясалган ныгытма. *Алар, окоптан чыгып, тимерчыбык киртәләрне үтеп, мылтык яңгыраган якка таба киттеләр.* М. Гали. *Саперлар бер тар участокны миналардан арчыйлар, тимерчыбык киртәне кисәләр.* А. Шамов.

3. *күч.* Комачау, тоткарлык. *Күршем инде, билгеле, Киртә миңа һәр эштә.* М. Җәлил. *Рус булмаган милләт балалары да укуга сәләтсез булмаган, тик аларның юлларында киртәләр зур булган.* И. Рәмиев. || Нәрсәнең дә булса ахыры, чиге. *Яхшылыкның киртәсе юк.* Г. Галиев.

◇ **Киртә булу (кору, кую)** — нинди дә булса эшкә, хәрәкәткә һ. б. комачаулау, тоткарлык ясау; каршы килү. *Һичкем безгә киртә була алмас Бер-беребезне яныпсөяргә.* Ф. Бурнаш. *Институтны тәмамлагач уқ* [*аспирантурага*] *калмакчы идем, практик стажың юк дип, киртә кордылар.* Б. Камалов. **Киртә сикерү** — әдәпсезләнү, артык тыйнаксызлану, тәртипсезләнү; башбаштаклану. [*Бозылды дипә*], *бөтенләй киртә сикерде.* Г. Бәширов. — *Болай киртә сикерә*

башласаң, иртәгә бөтен колхозны [сиңа каршы] котыртачакмын. Ф. Хөсни. **Киртәгә сыймау** — әдәп нормаларына сыймау, туры килмәү. *[Илгизәрнең] әлеккеге юньсезлекләре ничектер киртәдән чыкмый иде, ә монысы аның бернинди киртәгә дә сыймый.* Г. Әпсәләмов. **Киртәдән чыгу** — 1) кабул ителгән нинди дә булса нормаларны бозу. — *[Каюмның] юлы да безнең идея киртәсеннән читкә чыкмый.* Ш. Камал; 2) зур тәртипсезлекләр, начарлыклар эшләү; бозылу. **Киртәсенә керү (кертү)** — беркадәр яраплык, канәгатьләнерлек хәлгә килү (китерү). *Ноктала да төртмимен, керсә ярар, дип, киртәгә, Мин үзем сызганны үзем бик яхшы таныйм, дип, иртәгә.* Г. Тукай. — *Альфред, менә [шушы мәкаләне] төзәтеп, киртәсенә кертеп дигәндәй, языйк әле.* А. Расих.

КИРТӘЛЕ *с.* Киртәләп алынган, киртәләнгән. *Киртәле кибәнгә мал кермәс.* Мәкаль.

КИРТӘЛЕК *и.* 1. Киртә тоту өчен яраклы агач. *[Хәйдәр белән Карлыгач], күпме киртәлек кирәк буласын белү өчен, бакча әйләнәсен үлчәргә тотындылар.* Г. Бәширов.

2. Киртә (2 мәгъ.) белән әйләндереп алынган урын. *Юан бүрәнәләрдән салынган такта түбәле --- өйдән ерак түгел, киртәлек эчендә, печән кибәннәре каралып күренәләр.* С. Рафиков. || *күч. сөйл.* Комачау, тоткарлык. *Иркәлек — кеше булуга киртәлек.* Мәкаль.

КИРТӘЛӘҮ *ф.* 1. Киртә белән әйләндереп алу, киртә тоту (ишек алдын, бакча тирәсен һ. б.). *Җәләл саламын бик зур эскерт итеп --- өйдерде дә, малфәлән кагылмасын өчен, тирәсен киртәләтеп куйды.* Г. Ибраһимов. — *Бай башы белән, саранланып, ындырын юнәтеп киртәләми дә үзе, аннан [мал] иясенә гаеп була.* М. Фәйзи.

2. *күч.* Тоткарлау, кыенлаштыру (алга таба хәрәкәт итүне). *[Урал күпере] дошманның юлын киртәләргә безгә ярдәм итте.* Ш. Камал. *Һаваларга ашып торган агачлар арасын тутырып аркылы-торкылы үскән куаклар юлыбызны киртәлиләр.* А. Шамов. || Тоткарлап тору, туктату. *Сугыш сөреме киртәли Диңгездән искән җилне.* Г. Хуҗиев.

3. *күч.* Саклау (һәртөрле бәла-казалардан, йогышлы авырулардан һ. б. ш.). *Бу дөньяда сине кем иркәли соң? Бәла-казалардан сине кем киртәли соң?* Г. Тукай. *Бу фәрештә балага Сер дип исем бирик тә Асырыйк аны иркәләп, Авырлыктан киртәләп.* Ф. Бурнаш. || Тыю, чиклә̆ү (теләк, хис, омтылышларны). *Бусы артык, бусы ярамый дип Киртәләдек яшьлек хисләрен.* М. Җәлил.

КИРТҮ *ф.* Кирт ясау; почмаклап кисеп, уеп алу. *Сарыкның колагын киртү.*

КИРЧЕГӘ *и. диал.* Кирелек, каприз. *Һәр скважинаның үз холкы, үз кирчегәсе була — без әле шуны өйрәнеп бетмәгән.* Р. Төхфәтуллин.

КИРЧЕГӘЙЛӘНҮ *ф. диал.* Киреләнү, капризлану. *Фигыльләрнең күпбуынлы, катлаулы сурәт [белдерүче төренә] берничә төшенчә элементларыннан торган фигыльләр кереләр: акыллы башлану, кирчегәйләнү һ. б.* Л. Җәләй.

КИРӘГЕНДӘ, КИРӘКТӘ *рәв.* Кирәк булганда, кирәк булган очракта. *Зариф, Җәләлгә якын адәм булып, кирәгендә акча да алгалый, ярдәмгә мөрәҗәгать итә торган иде.* Г. Ибраһимов. *Давыл сүнәр, бәлки, йөрәктә, Ул табылмас, бәлки, кирәктә.* Һ. Такташ.

КИРӘГЕ'НЧӘ *рәв.* Кирәк булганча, тиеш дәрәҗәдә, җиренә җиткереп. *Баганалар кирәгенчә нык утыртылган.* Ш. Камал. *[Яшь агач:] Тамырларым да, шушы карт Агачлар тыгызлаганга күрә, кирәгенчә җәелә алмыйлар.* Г. Тукай. *Авылда зур вакыйгалар булачагына ышандырган приказ крестьяннарны кирәгенчә шатландыра да, ышандыра да алмады.* Х. Кәрим.

КИРӘГӘ *и. этн.* Тирмәнең (күчерелмә киез өйнең) кабыргалык агачлар челтәре, киергесе. *Кирәгә утырту.* □ *[Азымбай], ишектән аягын атлауга, тирмәнең эчендәге байлыкка, кирәгә буйлап тезелгән буяулы сандыкларга --- күзләрен йөртте.* Г. Ибраһимов. *Кирәгәнең киезләрен күтәреп, тыңлаучылар берсе өстенә берсе ябырылалар.* И. Салахов.

КИРӘГҮ *ф.* Кирәк булу. *Кирәкмәгән киерге иртәгә кирәгер.* Мәкаль. *Шигырь чыгарырга син кирәкәч, Ашыгып кайттым синең яныңа.* Х. Туфан.

КИРӘК *хәб. сүз.* 1. Таләп ителә; булуы тиешле, зарур. *Көрәш мәйданында җиңәр өчен Утка каршы көчле ут кирәк.* М. Гафури. — *Зур мәсьәлә бу. Моңа озак вакыт кирәк.* Р. Ишморат. *Дөньяда дуслыш кирәк.* Ә. Фәйзи.

2. Кемгә яки нәрсәгә дә булса ихтыяҗ булу. — *Миңа Мәрдән абзый кирәк.* Г. Гобәй. — *Байлык миңа кирәк түгел, Кирәк түгел асыл зат.* Т. Гыйззәт.

3. *-ырга* || *-ергә, -рга* || *-ргә* формасындагы фигыльләрдән соң килгәндә тиешлек, мәҗбүрилек мәгънәсен белдерә. *Һәр эшне урынын белеп эшләргә кирәк.* Г. Тукай. — *Терлекләрнең нәселләрен яхшыртуны планлы рәвештә алып барырга кирәк булыр.* Ә. Еники.

4. „Булырга“ фигыле һәм шарт фигыльләр белән килгәндә аныклык раслый алмау, чамалап әйтүне белдерә: бугай, ахры. *Шүрләгән булырга кирәк.* □ *Халкыбыз --- бу ялганчыларның хәйлә вә мәкерләрен аңласалар кирәк.* Г. Тукай.

5. *с. мәгъ. к.* кирәкле. *Иртәгә кирәк дәресләрне Вәли кичтән укый.* М. Гафури. — *Яшелчә бакчасы өчен бик кирәк нәрсә ул [водокачка].* Ш. Камал. — *Әйдәгез, Сәхип әфәнде, бик кирәк чакта килдегез.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

6. *и. мәгъ. кыек килеш форм.* Ихтыяҗ, кирәк булган нәрсә, кирәк-яраклар. *Өй кузгаткач, аның кирәге күп була икән.* Г. Ибраһимов. *Ильясның һәрнәрсәсе ирешкән вә һәр кирәге җитешкән иде.* Г. Тукай. *Зәңгәр күлмәк, ак яулык, Шул минем кирәкләрем.* Ш. Маннур.

7. Берәр кешенең яки берәр нәрсәнең кирәклеге, кирәк булуы. *Бир гомереңне көрәш өчен, Шунда безгә синең кирәгең.* Ф. Кәрим. — *Кирәгем булыр дисәң, мин сиңа таянырга җилкәмне ышандырам.* Э. Касыймов.

8. *җыю. терк. функ. кит.* Тиңдәш кисәкләр алдыннан кабатланып килеп, аларны берләштерә, фикергә көчәйтү төсмере өсти („һәм“ теркәгече белән алыштырырга була). *Кунаклар киткәч, кирәк Маһитап абыстай, кирәк кызы Сәмигулла абзыйны бик нык орыштылар.* Ф. Әмирхан. *Трагедия жанры, әлбәттә, кирәк язучыдан, кирәк театр коллективыннан зур осталык, кыюлык таләп итә.* Каз. утл.

9. *кире шарт терк. функ.* Кире иярчен җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла (гадәттә шундый җөмләнең тиңдәш кисәкләре алдыннан кабатланып килә). *Йөзегездә ачулану күренмидер, Кирәк төннәр җылы булсын, кирәк тымык.* М. Гафури. *Кирәк ачулан, кирәк кыйна — хәзер һич файдасы юк.* Шура.

◇ **Кирәге бар (иде)** — „кирәге юк“ мәгънәсендә, кимсетеп, ирония белән әйтелә. *Чынлап та, Госман кыстаган өчен минем янга керә торган әсманың минем өчен күпме кирәге бар?* Ф. Әмирхан. **Кирәге бер тиен** — кирәк түгел, кирәге юк. **Кирәген алу** — тиешле җәзага тартылу. *[Фәтхерахман әтәригә:] Авызыңны ерып күп сөйләшеп йөрсәң, кирәгеңне*

алырсың. Г. Камал. **Кирәген бирү** — 1) бик каты тиргәү, шелтәләү яки тәнкыйтьләү. — *Хөрбануның уңаена килмәсәң, кирәгеңне бирә инде ул.* М. Фәйзи; 2) бик каты кыйнау, җәзалау. *Лотфуллаң кычыткан белән кирәгемне бирә генә бит.* Ә. Айдар. — *Борчылмагыз, иптәш начальник, штыксыз да без аларның [бандитларның] кирәген бирербез.* А. Шамов; 3) җәфалау, интектерү, бик каты йөдәтү. — *Сыра белән аракы катнашты исә, кирәкне бирә инде ул.* Ш. Камал; 4) нәрсәне дә булса бик тырышып, ләззәтләнеп эшләү, уңышлы башкару. — *Мин, Рәхим абый, - - - икс ларның кирәген бирәм монда.* Һ. Такташ; 5) нәрсәдән дә булса тулы канәгатьләнү алганчы, бик яхшы файдалану. *Кирәген бирдем җилләкләрнең. Туйганчы ашадым.* **Кирәгеннән артык** *ирон.* — бик ник. — *Җитте, җитте, днвәр. Кирәгеннән артык аңлашылды.* Р. Ишморат.

КИРӘК-КИРӘКМӘГӘН *с.* 1. *к.* кирәк-кирәкмәс. *Кирәк-кирәкмәгән эшләргә катнашу.*

2. *рәв. мәгъ.* **кирәк-кирәкмәгәнгә, кирәк-кирәкмәгәндә.** Урынсызга, тиешсезгә, сәбәпсез. *Сания, прнсканың бөтен яхшы-яман якларын белеп торса да, кешеләрне кирәк-кирәкмәгәнгә чәйнәргә яратмый.* И. Туктар.

КИРӘК-КИРӘКМӘС *с.* Тиешсез, ярамый торган. *Кирәк-кирәкмәс эшкә тыгылырга ярату.* || Мәгънәсез. *Галимә апа - - - кирәк-кирәкмәс сүзләр әйтә.* М. Гафури.

КИРӘКЛЕ *с.* Кирәк булган. [*Муса Солтанга:*] *Кирәкле кешеләрнең барына дамы хәбәр иттең?* Ф. Бурнаш. || Әһәмиятле, мөһим, файдалы. *Кирәкле эш. Кирәкле сүз.* □ *Беркөнне Гафиятулла абзый - - - бик кирәкле бер йомыш белән авылга кайтып китте.* Г. Әпсәләмов. *Минемчә, фронт лирикасы да, бигрәк тә хәзер, кирәкле һәм мөһим жанр.* М. Җәлил.

◇ **Кирәкле кишер яфрагы** *ирон.* — кирәксез, файдасыз кеше турында. [*Фазыл:*] *Без синең белән кемнәр әле? Кирәкле кишер яфраклары бит, шулаймы?* Ә. Фәйзи. **Кирәкле кул** — нинди дә булса эштә, берәр мәсьәләне хәл итүдә зур ярдәме, файдасы тия торган кеше. *Уги килен бөтен мәҗлес вакытында гажәп дәрәҗәдә кирәкле кул булып китте.* Г. Ибраһимов.

КИРӘКЛЕК *и.* 1. Кирәк булу, зарурлык. [*Мансуров*] *Нәфисәнең киләчәге, аны нинди юл белән үстерергә кирәклек турында уй йөртте.* Г. Бәширов. *Театрның кирәклеген тормыш үзе таләп итә.* Ә. Фәйзи. || Тиешлек, тиеш булу. — *Райком үз сүзен кайчан әйтергә кирәклеген белә ул.* А. Әхмәт. *Һәрбер кеше тигез булу кирәклеген Ир түгел, ошбу көндә белде хатын.* М. Гафури.

2. Ихтыяҗ, хаҗәт. — *Син, Гыймади, [Озын Хөсәеннең] сөйләгән сүзләрен ишетсәң иде, менә безнең кирәкләкләрне әйтә дә бирә.* Һ. Такташ.

КИРӘКЛЕ-КИРӘКСЕЗ *с.* Кирәк һәм кирәк булмаган, әһәмиятсез, төрле вак-төяк. *Кирәкле-кирәксез сүз сөйләү. Кирәкле-кирәксез әйберләр җыйнау.*

КИРӘКЛЕ-КИРӘКСЕЗГӘ *рәв.* 1. Сәбәпсез, юк-бар нәрсәләр белән. *Кирәкле-кирәксезгә борчу.*

2. Максатсыз, кирәге булмаган килеш. *Кирәкле-кирәксезгә кереп-чыгып йөрү.*

КИРӘКЛЕЛЕК *и.* Кирәкле булу, зарурлык.

КИРӘКМӘГӘНГӘ, КИРӘКМӘСКӘ *рәв.* Кирәк булмаган килеш; сәбәпсез, юкка, урынсызга. — *Монда сезнең һич кирәкмәгәнгә шаулашалар икән.* Г. Камал. *Бер юньсезе кирәкмәскә баз казып куйган.* А. Алиш.

КИРӘКСЕЗ *с.* Кирәге булмаган, кирәк түгел; әһәмиятсез. *Акмаган сулар кадерсез, Файдасыз һәм кирәксез.* Ә. Ерикәй. *Художество әсәрләрен кирәксез детальләрнең күп булуы боза.* Ә. Исхак.

КИРӘКСЕЗГӘ *рәв. к.* кирәкмәгәнгә. *Картны бер дә кирәксезгә тагын да ачуландырырга теләмичә, [Мохтар] сүзне бөтенләй икенче якка борып җибәрергә кирәк тапты.* Ш. Камал.

КИРӘКСЕЗЛЕК *и.* Кирәксез булу, кирәк түгеллек, әһәмиятсезлек. *Мөдәррис үзе, бу сәндерәләрнең кирәксезлеген сизсә дә, аларны алып ташлату өчен бай белән киңәш итүнең уңаен таба алмый.* Ә. Фәйзи.

КИРӘКСЕНҮ *ф.* 1. Кирәк дип табу, кирәк дип санау. *Галләм абзыйлар Нәгыймнән сакланырга кирәксенмәделәр.* М. Гафури. *Безнең моннан ике-өч ел алдан кирәксенгән нәрсәләребез үтәлделәрме?* Ф. Әмирхан.

2. Кемне яки нәрсәне дә булса теләү, шуңа ихтыяҗ булу. *Каты нәрсә аның [этинең] тамагына үтми, чәйгә сөт кирәк, җылы шулпа да кирәксенә.* Г. Ибраһимов.

КИРӘК-ЯРАК *җый. и.* Берәр төрле эшкә яки нәрсәгә кирәкле төрле әйберләр, әсбаплар, җиһазлар һ. б. *Туй кирәк-яраклары. Юл кирәк-яраклары.* □ [*Зиннәтнең*] *уку йортына төрле кирәк-ярак аласы бар иде бит.* Г. Бәширов. *Гаскәр йончыды, сафлар сирәгәйде, корал, сугыш кирәк-яраклары кимеде.* Г. Гобәй.

КИРӘМӘТ *и.* 1. Карама төреннән булган агач (хәзер сирәк очрый). *Мариның мәңге шомлы кирәмәте белән яши миндә бу як.* С. Хәким. *Әптери агай - - - кыр уртасында, кирәмәт агачы янында куып җиткән теге егетне.* Г. Әпсәләмов.

2. *иск.* Табына торган илаһи көч, рух (мариларда, чувашларда, чукындырылган татарларда, мәҗүсилекнең бер төре буларак, кирәмәт агачын аллалаштыру, шуңа табыну йоласы булган). *Ачлык заман булса, борын заман Чуваш килеп шуңа [кирәмәт агачына] табынган. - - - Теләгәннәр шулай кайтарырга Кирәмәтнең шомлы каргышын.* Ш. Мөдәррис. || Кирәмәткә табынучы. *Болгармы бу, келәү йортымы, Тулган җыен кирәмәт имчесе.* Н. Исәнбәт.

3. *күч. сөйл.* Нинди дә булса бик начар, фаҗигале эш, хәл турында. *Хәзер инде андый кирәмәтләр [корылык, ачлык һ. б.] бик аз очрый дала ягында.* Ш. Мөдәррис. || *с. мәгъ.* Холыксыз, кире беткән; әкәмәт. *Кирәмәт кеше.*

4. *күч. сөйл.* Көтелмәгән, гажәпкә калырлык эш яки аңларга, файдаланырга читен булган берәр нәрсә турында. [*Шикле кеше:*] *Әнем ... Менә сиңа кирәк булса кирәмәт.* [*Ящь егет:*] *Монда бер дә кирәмәтмазар юк, тотканнар да [Галимҗан белән Нәфисәне] өйләндергәннәр, ә синең әтиеңнең исемен дә сорап тормаганнар.* Ф. Бурнаш. *Белер өчен ныклап өйрәнергә кирәк ул кирәмәтне [прессны].* Чаян.

КИРӘҮ *и. диал.* Берәр корылманың нигез формасын тәшкил иткән агач яки тимер челтәр, киерге. *Вагоннар, көпчәк-күчәрләреннән ычкынып, читкә очкан, агач өлешләре янып беткән, тимер кирәчләре, көзән җыергандагыдай, төрлечә кәкрәешеп катканнар.* М. Рафиков.

КИРӘҮКӘ *и. иск.* Металлдан эшләнгән кием. *Башына бакрач, өстенә кирәүкә кигән берәү шәйләнә.* Н. Исәнбәт.

КИСАП *и. сөйл.* Киле сабы. *Исәбенә күрә хисабы, килесенә күрә кисабы.* Мәкаль.

КИСЕК *с.* Киселгән, кисеп алынган. *Юк аягы, гәүдәсе һәм кулы, Бер кисек баштыр, һаман сөйләр теле.* Г. Тукай. [*Зәйтүннең*] *башында кисек урын күренмәде.* Ф. Яруллин.

КИСЕКБАШ *и. зоол.* Төнге күбәләкнең бер төре (аркасында кешенең баш сөяге сыман сурәте була); *русчасы:* адамова голова.

КИСЕЛЕШ *и.* 1. Нәрсәнең дә булса киселү рәвеше. *Поршень балдаклары киселеше.*

2. *к.* кисем. *Цилиндрның аркылы киселеше.*

КИСЕЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* кисү. *Кайчысыз киселә, Җепсез тегелә.* Табышмак.

2. Таушалу, теткәләнү. [*Әхмәди*] *озак йөрүдән читләре киселә башлаган сары конвертны кабаланып ачарга тотынды.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Бүленеп калу, аерылу. *Соңгы айларда без дөньядан киселгән идек.* Г. Әпсәләмов. *Ялгыз калып, киселеп тордык бар дөньядан.* М. Гафури.

4. *күч.* Тукталу. *Сугышның икенче елында Шакирдан кинәт хат киселде.* Г. Минский. — *Безнең арада нидер булган икән, шуның белән киселсен.* Э. Касыймов. || Бетү, калмау. *Өмет киселү.* □ *Эш ташлагач, аларның [көнлекчеләрнең] килере киселде.* Х. Садрый.

5. *күч.* Һәлак булу, кырылу, юкка чыгу. *Кешеләр сугыша, кан коя, Киселә меңнәрчә гомерләр.* М. Җәлил. *Көтелмәгән бу һөҗүмнән дошман бик нык киселде.* Г. Кутуй.

6. *күч.* Артык дәрәҗәдә ябыгу, йончу, хәлсезләнү. *Җиңел эчемлек булса да, лагерьда киселеп беткән бу егетләрнең башына менеп алды ул.* Ш. Маннур.

7. *рәв. мәгъ.* **киселеп.** Нык, һич онытылмаслык булып. *Болай ваклап чәйнәп йоттырган нәрсә аның хәтеренә киселеп керде.* Г. Ибраһимов.

◊ **Киселеп йөрү** *ирон.* — нәрсә дә булса эшләргә, кемдер булып күренергә тырышу. — *Дус булып киселеп йөргән була бит әле үзе, серләрен сөйләгән була.* Ш. Маннур. *Социалист булып киселеп йөргән, демагоглыгы белән шөһрәт тапкан Тукмаков: — Җәмәгать! Тагын бер сөенеч!.. — диде.* К. Тинчурин.

КИСЕМ *и.* Предметны кисеп алган урында барлыкка килгән өсйөз. *Тимерчыбыкның аркылы кисеме. Буй кисем.*

КИСЕМТӘ *и.* 1. *мат.* Туры сызыкның ике яктан чикләнгән кисәге. *Кисемтә очы. Пропорциональ кисемтәләр төзү.*

2. Газета-журналлардан кисеп алынган аерым текстлар, мәкаләләр. *Газета кисемтәләре.*

КИСЕНТЕ *и.* 1. Әйбернең кисеп, чабып алынган бер кисәге. *Такта кисентеләре.* □ *Берәүләр мул яфраклы вак, нечкә ботакларны пычак яки балта белән кисеп ала торсалар, икенче берәүләр шул кисентеләрне --- аланлыкка ташыдылар.* С. Рафиков. *Мостафа --- лобогрейканың почмагына җыйнала торган кисенте өемнәрен җиргә төшереп җыйбәрүнең техникасы турында [Фәтхигә] бераз аңлатма бирде.* Ш. Камал.

2. *к.* кисем. [*Йосыф өрәңге*] *кисентесендәге тамчыларны күргәч, авыр гына сулап: — Бүген кискәннәр... — дип уйлады.* К. Нәҗми.

3. *к.* кисентек. *Урман кисентесе.* □ *Бригадир анда-санда гына аударылмый калган наратлар белән чуарланган киң кисенте буйлап китеп барды.* Г. Әпсәләмов.

4. Арба көпчәкләре эзендә хасил булган чокыр-чакыр. *Көзге пычракта бозылып калган урамнар, юллар бөтен казылмалары, кисентеләре һәм чокырлары белән бер төн эчендә шакыраеп каталар.* Г. Бәширов.

5. *тар.* Россиядә 1861 елгы крестьян реформалары вакытында крестьяннарның имана җирләреннән кисеп алынган участок, алпавытлар тарафыннан крестьяннардан тартып алынган җир. *В. И. Ленин авылда крепостнойлык калдыкларын бетерү, --- „кисентеләрне“ крестьяннарга кайтару таләбен куйды.* КПСС тарихы.

КИСЕНТЕК *и.* Агачлары киселгән урман урыны, ачык мәйдан. — *Кисентекне чыгу белән бер чишмә бар, шунда ашап алырбыз да кайтып китәрбез.* Г. Галиев. *Бик матур, һавасы саф булган кисентеккә кергәч, Зәки әкренрәк атлый башлады.* Х. Мөҗәй.

КИСЕНТЕЛЕК *и. к.* кисентек. *Алар кисентелек буйлап баралар иде. Хәзер монда бары тик яшь агачлар гына үсә.* Г. Әпсәләмов.

КИСЕТ *и. сөйл.* Гадәттә чигеп яки төрле төстә бизәп эшләнгән тәмәке янчыгы. *Кайсы кисет чигә, кайсы йон эрли.* М. Шабай. [*Зөбәржәт:*] *Микъдат, иреннәреңне салындырып утырсаң, мә балдагың, бир кисетем.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КИСЕШ *и. сөйл.* Сугыш, үтереш. — [*Яралыны*] *ераграк алып китегез. Монда хәзер кисеш булачак.* И. Гази.

КИСЕШҮ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* кисү (1, 2, 6, 7 мәгъ.).

2. Бер-берсен кисеп үтү. *Сызыкларның кисешү ноктасы. Юллар кисешкән урын.* □ *Идел артыннан, сихерле тасмалар кебек, прожектор утлары күккә сузылган. Алар бер-берсенә очрыйлар, кисешәләр.* Х. Садрый.

3. *күч. сөйл.* Сугышу, суешу, бер-береңне үтерү.

КИСЕЯ *и.* 1. Үтә күренмәле җиңел тукыма. *Тәрәзә пәрдәләре ак бүздән яки кисеядән була.* К. Насыйри.

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Кисея шарф.* □ *Өй тәрәзәсенең кисея пәрдәсе җиңелчә дулкынланып китте.* Ф. Әмирхан.

КИСКЕН *с.* 1. Чагылышы бик көчле булган, бик нык тәэсир итә торган. *Кискен нәфрәт. Кискен ачу.* □ *Яфраксыз агач башларындагы чыбыкларны кискен март җиле чайкалдырып тора.* Ш. Камал. *Колак төбендә мастерның кискен, ышанычлы сүзләре яңгырый.* А. Әхмәт. || Артык ачык, үтә көчле (сизү органнарына тәэсире буенча). *Сарае зур, нәкышләнгән, әнҗеләнгән; кискен нурлар сибелеп тора әнҗеләрдән.* Һ. Такташ. — *Аһ... Йөрәгем!.. Үләм! — дигән әче, кискен тавыш колакларны ярып җибәрде.* Г. Ибраһимов.

2. Хәлиткеч; бик каты. *Кискен бәрелеш.* □ [*Мөршидә Мәхмүзәгә:*] *Я иртәгәдән башлап эшкә йөри башлыйсың, я без сиңа Устав нигезендә кискен чара күрәбез.* Р. Ишморат. *Кул суза җирәнгеч фашистлар Бәхетле илдәге уңышка. Сугышка, иптәшләр, иң соңгы, Иң каты, иң кискен сугышка!* Ә. Ерикәй.

3. Бик катлаулы, киеренке. *Кискен минутлар. Хезмәт белән капитал арасындагы сыйнфый каршылыклар кискен характер алу.* || Авыр, кыен. [*Балалар йорты мөдире:*] *Балалар! Хәл кискен. Бик күп нәрсәләр җитешми.* А. Алиш. || *рәв. мәгъ.* Ачык; калкурак итеп. *Бу момент [әсәрдә] кискенрәк итеп күрсәтелергә тиеш.* М. Җәлил.

4. Катгый, нык, аныk. [*Мансуров*] *Нәфисәгә тагын бер күтәрелеп карады да кискен бер фикергә килде.* Г. Бәширов. *Һичбер сүзгә вакыт калдырмыйча, Кискен җавап кирәк бу юлы.* Ф. Бурнаш. || *рәв. мәгъ.* Бик көчле, ачыктан-ачык. [*Гәрәйгә*] *моңарчы үлем бу кадәр якын килгәне, бу чаклы кискен сизелгәне юк иде.* Г. Ибраһимов.

5. Таләпчән, кырыс. *Эшкә чумган кешеләр арасында --- Отто да күренә, ул үткен һәм кискен приказлар бирә.* А. Алиш. — *Кулыңны күтәр! — дип, кискен тавыш белән кычкырды командир.* Ә. Әхмәт.

6. Усал, рәхимсез; килешмәүчән. *Кискен тәнкыйть.* □ *Син дошманга кискен Булган саен, Сине көрәш дусларың Ныграк сөйде.* М. Җәлил.

7. Кыю, тәвәккәл. *Хәйдәрнең кискен күз карашында шелтә күренде.* Г. Бәширов. *Гәүһәр кискен кеше*

иде. Г. Ибраһимов. | *рәв. мәгъ. Бу рейд яшен кебек тиз һәм кискен ясалды* А. Шамов.

8. Кинәт булган; бик ачык күренеп, сизелеп торган. *Монда [табигатьтә] матур музыкага тартымлы кискен алмашылык, төрлелек, матур гармония ярылып ята.* Ш. Камал. *Беркөнне дөнья кинәт һәм кискен рәвештә үзгәреп китә.* Г. Галиев. || Кинәт, көтмәгәндә булган. *Үзе ул [Мостафин] йомшак характерлы кеше, тормышның кискен борылышларын авыр кичерә.* Ә. Еники.

9. Бик кызу, җитез, нык. [*Хәлим*] *кискен адымнар белән басу капкасына таба атлый башлады.* И. Гази. *Секретарь кискен хәрәкәт белән урыныннан торды.* Г. Гобәй.

10. Үтә нык. *Кискен континенталь климат.*

КИСКЕНЛЕК *и.* Кискен булу сыйфаты. *Мәсьәләне бөтен кискенлеге белән кую.* □ *Күпер янында көрәшнең кискенлеге һаман да кимемәде.* К. Нәҗми. *Аның тавышында кискенлек, шелтә яңгырый.* А. Әхмәт. *Аюкин яныннан каударланып киткән Шәрифуллин көтелмәгән кискенлек белән яңадан борылып килде.* С. Рафиков.

КИСКЕНЛӘНҮ *ф. сир. к.* кискенләшү. *Тавыш кискенләнү.* □ *Каракаш әбинең күзләре кискенләнеп китте, йөзенә ачу бәреп чыкты.* М. Усманов.

КИСКЕНЛӘШТЕРҮ *ф.* Көчәйтү; катлауландыру, киеренкеләндерү. *1905 елгы революция М. Гафурида бу [халыкчанлык] карашларны тагын да тирәнәйтте, кискенләштерде.* М. Җәлил. [*Газизә*], *гүя Мохтарның күңеленә килгән сорауны кискенләштерү өчен, әткәсенең [сүзләрен куәтләде].* Ш. Камал.

КИСКЕНЛӘШҮ *ф.* **1.** Катлаулырак, киеренкерәк, куркынычлырак төс алу (нинди дә булса мөнәсәбәтләр, каршылыклар турында). *Халыкара хәл кискенләшү. Сыйнфый көрәш кискенләшү.* □ *Шәкертләр белән хәлфәләр арасы кискенләшә барды.* Ә. Фәйзи. || Авырлашу, кыенлашу. *Хәл сәгать саен, минут саен кискенләшә барды. Гаскәр йончыды, сафлар сирәгәйде, корал, сугыш кирәк-яраклары җитешмәде.* Г. Гобәй. || Үзара мөнәсәбәтләр кискен бозылу, начарлану. *Җәгъфәр белән ара көннән-көн катлаулана, кискенләшә бара.* Г. Әпсәләмов.

2. Усаллану, кырыслану. *Егет тагын үзгәрә, кискенләшә төште:* — *Атай, бу ни кылганың синең?* Г. Ибраһимов. *Гаяз кинәт кызарды, кинәт агарды. Күзләре кысылып кискенләштеләр.* М. Әмир.

3. Ныграк тәэсир итү, үткенләнү. [*Сөләймановның*] *тыныч, сабыр гына сөйләгән сүзләре торган саен көчәя, кискенләшә, хәтта усаллана барган кебек иде.* Ә. Еники.

4. Үтә кызулану, җитезләнү. [*Картның*] *йөрешләре, хәрәкәтләре, бар дөньясын берьюлы җимереп ташларга җыенгандай, кискенләшә, хәтәрләнә.* Р. Төхфәтуллин.

КИСКЕЧ *и.* Металл, агач һәм башка каты әйберләрне кисү, эшкәртү өчен кулланыла торган корал. *Кыру станогы кискече. Пыяла кискеч.* □ [*Сафихан абзый*] *кискечләр, кечкенә чүкечләр, ышкылар - - - белән тулы шүрлекләргә шактый гына вакыт өнсез калып карап торды.* Г. Мөхәммәтшин. || *с. мәгъ.* Кисә торган, кисү өчен җайланган. *Кискеч төрән.*

Кискеч теш *анат.* — алгы яссы теш. *Үткен кискеч тешләре белән агачны кимереп,* [*күсе*] *үзенә чыгарга юл ясый.* Зоология.

КИСКЕЧТАШ *и. археол.* Таш дәверендә: сөякләрне, мөгезләрне, таш токымнарының кайбер төрләрен эшкәртү өчен очлы пластинка рәвешендә чакматаштан ясалган корал.

КИСКӘ *и.* Юан агач кисентесе; түмәр, бүкән. *Балта кискәнче, кискә ял итә.* Мәкаль. *Ишек алдында бер кискә, Ватып бәр, анакай, бер мичкә.* Жыр. || *күч.* Каршылык, киртә. [*Фатыйма бикә*] *кызының олуг бәхетенә ирешү юлында кискә булып яткан Зыяның язмыш кулы илә алып ташлануына чыннан да куана иде.* Г. Ибраһимов.

КИСКӘЛӘНҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* кискәләү.

2. Киселү, яргалану (җилдән, селтеле судан, бәрелүсугылудан һ. б.). *Тәгәзимә уң кулына карап алды. Чыннан да, аның кулы каралып, кискәләнеп, катып беткән иде.* А. Расих.

КИСКӘЛӘҮ *ф.* **1.** *Каб. дәр. к.* кисү (1, 2, 4, 5 мәгъ.). *Китапны кискәләү. Кыяк үлән кулны кискәләп бетерү.* □ *Зәңгәрсу һаваны телем-телем кискәләп, вокзал өстендә карлыгачлар оча.* А. Гыйләҗев.

2. Кисеп, вак кисәкләргә, кисәкчекләргә бүлү, аеру. *Бүрәнәне кискәләү.* □ *Бәлешне кире алып чыктылар һәм кискәләп яңадан керттеләр.* Ә. Фәйзи. *Газизә, Төхфәтнең каршына утырып, алма кискәләп бирде.* Ш. Камал.

КИСЛОРОД *и. хим.* Һава составында сулау һәм яну өчен кирәкле, водород белән кушылганда су хасил итә торган химик элемент, газ. *Суларга кислород җитмәү.* □ *Сөт кислотасының бер молекуласында өч атом углерод, алты атом водород, өч атом кислород бар.* А. Расих.

Кислород мендәре — медицинада кислород сулату өчен кулланыла торган резиналы брезент капчык. *Миңа кислород мендәрләреннән кислород испәттеләр.* Г. Әпсәләмов.

КИСЛОТА *и. хим.* Тоз барлыкка килгәндә составындагы водородны металл белән алыштыру сәләтенә ия булган, гадәттә әче тәмле химик кушылма. *Азот кислотасы. Сульфат кислотасы.* □ *Кырмыскалар еланны аның саен катырак тешләделәр, үзләрендәге кислотаны елан тәненә җибәрделәр.* А. Алиш.

КИСЛОТАЛАУ *ф.* Кислота белән эшкәртү.

КИСЛОТАЛЫ *с.* Составында кислота булган, кислота кушылган; кислота салынган. *Кислоталы эремә. Кислоталы кушылмалар. Кислоталы буяулар.* □ *Клара, ялгышмы-ничекме, кислоталы колбаны төшереп ватты.* Э. Касыймов.

КИСЛОТАЛЫЛЫК *и.* Кислоталы булу сыйфаты, хәле. *Табылган әйберләрнең [озак] саклануына һава кермәү, сазлыкның кислоталылык дәрәҗәсе - - - ярдәм иткән.* Робинзон әзл.

КИСМӘ *с.* **1.** *махс.* Бертигез формадагы кәгазь, картон кисәкләренә язылган яки басылган. *Кисмә әлифба.* □ *Әлифба укырга керешкәч, кисмә хәрефләр белән тактада һәм партада төрле күнегүләр үткәрелә.* Сов. мәк.

2. *диал.* Киселгән. *Менә шул кисмә урманны үтү белән кыр башлана.* Һ. Такташ.

Кисмә таш — таш ятмадан махсус машина ярдәмендә кисеп хәзерләнә торган төзү материалы. *Безнең колхозның фермасы үзе бер авыл. Анда стеналары кисмә ташлардан өелгән, түбәләре ап-ак шифер белән ябылган бик киң сыер абзарлары, ат сарайлары, - - - тагын нинди генә корылмалар юк!* Г. Галиев.

КИСМӘК *и.* Юан агачның эчен куышлап яки такталадан коршаулап ясалган зур агач савыт, агач мичкә. *Су кисмәге. Бал кисмәге.* □ *Сәйфи, иелә төшеп, Мәүлиха белән әпипә арасында торган юкә кисмәктән бер уч бодай алды.* Г. Бәширов. *Кисмәгенә күрә коршавы.* Мәкаль.

КИСМӘН *и. зоол.* Корты (личинкасы) үзагач белән туклана торган зарарлы коңгыз; агач коңгызы; *русчасы:* дровосек. [*Тукраннар*] *юкә агачына очып килеп төшкәннәр, кисмәннәрне әзләргә керешкәннәр.* Ж. Тәрҗеманов.

КИСТЕРЕШЛЕ: кистерешле сорау алу *махс.* — бер үк кешедән ике яклы сорау алу (гаепләүче һәм гаепләнүче яки прокурор һәм яклаучы һ. б. тарафыннан). *Яклаучы --- һәм гаепләүчеләрдән берәү, фикеремне чуалтырга теләп, ике яклап сорау бирәләр. Бу — аларча кистерешле сорау алу икән.* Ш. Рәкыйпов.

КИСТЕРҮ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* кисү (1—10 мәгъ.). *Чәч кистерү. Кием кистерү.* □ *— Әгәр дә суземне тыңламасаң, әтиеңә әйтеп кистерермен.* Т. Гыйззәт.

2. Орынма сугу, бәрү белән (шарны, тупны) тиешле урынга юнәлтү (биллиард, футбол, волейбол һ. б. ш. уеннарда).

3. *күч. сөйл.* Кискен, катгый бер фикергә, карарга килү. *— Бардыр, берәр күңелсез хәбәр бардыр, — дип, [Нәгыймә] эченнән кистереп куйды.* Г. Ибраһимов. || *рәв. мәгъ.* **кистереп.** Өзеп, ачык итеп. [*Мохтар кемгә*] *барып чыгарга кирәклекне кистереп билгеләмәгән иде әле.* Ш. Камал. *— Ник алай бик кистереп әйтәсең, туганым-җиңги?* Ф. Хөсни.

4. *күч. сөйл.* Кайбер фигыльләр урынына кулланылып, шул фигыльдән аңлашылган эшнең бик кызу, интенсив, оста башкарылуын белдерә. *Аяксыз пулеметчы аларны [дошманны] якын җибәрми — кистерә генә!* Г. Әпсәләмов. [*Наташа*] *сүзгә бик үткен нәрсә икән, кистереп кенә салды.* Г. Бәширов.

КИ'СТОЧКА *и. сөйл.* Нәрсәнең дә булса өстенә буяу, җилем һ. б. ш. ягу өчен сапка беркетелгән кыл, чәч бәйләме; кечкенә пумала. *Мин, буяулар, кисточкалар салынган этюднигымны күтәреп, Зөя буена [төштем].* Б. Камалов.

КИСТӘН *и.* Кыска таякның бер очына чылбыр яки каеш ярдәмендә тимер шар, гер һ. б. ш. авыр әйбер беркетелгән, ә икенче башында кулга кию өчен әлмәге булган борынгы сугыш коралы. [*Шәйхи:*] *Алай-болай була калса, уң кулга кистәнне, сул кулга күсәкне, билгә балтаны кыстырып, --- поход чыгарга ризамын.* К. Тинчурин. *Егетләр, җиңнәреннән кистән чыгарып, Зәки алдында селкенгәләп куйдылар.* Х. Мөҗәй.

КИСӘК I *и.* **1.** Бөтеннең өлеше. *Бер кисәк алтын яки көмешне бик вак кисәкләргә бүлеп була.* Г. Тукай. || Бүленгән, сындырып алынган, ватылган өлеш. *Мин бер кисәк антрацит таптым.* Х. Туфан. *Бу шәһәрдә каты сугышлар булган. Йортлар җимерелгән, урамнарда йөрерлек түгел — таш, кирпеч кисәкләре өелеп ята.* Г. Бакиров. || Телем, сынык (ипи, сыр, карбыз һ. б. турында). *Куенга бер кисәк икмәк белән берничә бәрәңгене кыстырып, тагын [кырга] чыгып чабабыз.* Г. Ибраһимов.

2. Нинди дә булса бер бөтен күренешнең, организмның, механизмның состав элементы. *Дөнья кисәкләре. Җөмлә кисәкләре.* □ [*Хуҗалардан ун процент эш хакы арттыруны*] *таләп итүне дә, төбендә, власть өчен көрәшнең бер кисәге итеп алга куярга кирәк.* Ш. Камал. *Тулы эчтәлекле, әдәби югары сыйфатлы либретто — операның органик кисәкләреннән берсе һәм нигезе.* М. Җәлил.

3. Берәр әсәрнең композицион өзеге, бүлеге. *Фатыйма, рояль янына утырып, ноталар сайлады, аннан соң залда „Фауст“ музыкасыннан бер кисәк яңгырады.* Ф. Әмирхан. *Язучы [„Матур туганда“ романының] --- икенче кисәген язу өстендә дә эшләде.* Г. Кашшаф.

4. Бериш әйбернең бер данәсе, стандарт берәмлеге. *Өч кисәк сабын.* □ [*Немец*] *пергаментка төргән өч кисәк нәрсә китереп безнекеләрнең алдына салды.* Ә. Еники. || Нәрсә дә булса тутырылган стандарт күләмле төргәк; *к.* пачка. *Биш кисәк чәй. Ике кисәк сабын порошогы алу.* || Беришле әйберләрнең берсе өстенә икенчесе тигез итеп салынган җыемыннан гыйбарәт төргәк (кәгазь әйберләр турында). [*Камали*] *өстәлгә бер кисәк акча куя.* Г. Камал.

5. *күч. сөйл.* Берәр кешене яки нәрсәне кимсетеп әйткәндә кулланыла торган тагылма сүз. *Бу бер офицер кисәге булса кирәк, киеме һәм билгеләре бүтәнчәрәк.* Ә. Еники. [*Гөлсем апаның*] *квартирасы --- авылча кара-каршы салынган кыйшык-мыйшык бер өй кисәгенең ярты ягыннан гыйбарәт иде.* Г. Гобәй.

6. *тарт. форм.* Үзеннән алда килгән „җан“, „бәгырь“ сүзләре белән берлектә иркәләп, назлап мөрәҗәгать итү тәгъбире буларак кулланыла. *— Кара әле, Фәтхерахман, синең ашыйсың килә торгандыр бит, җан кисәгем.* Ш. Камал. *Актык күрүләрем булса, Сау бул, бәгырь кисәгем.* Җыр.

КИ'СӘК II *рәв. сөйл.* Кинәт, көтмәгәндә. [*Рәхмәтулла*], *безнең авылга килеп, кисәк кенә авырып үлде.* М. Гали. *Ашыгучы кешеләрне [бу] күренеш кисәк үзенә тартты.* А. Алиш.

КИСӘК-КӨСАК *җый. и. сөйл.* Һәртөрле калдык, ташландык кисәкләр. *Сания кисәк-косаклардан курчагына күлмәк текте.* Г. Гобәй. || Ашамлык калдыклары.

КИСӘКЛЕ *с.* Кисәкләргә бүленгән, кисәк-кисәк итеп хәзерләнгән. *Кисәкле шикәр. Кисәкле сабын. Кисәкле ак май.* || Данәле, үлчәнми торган, кисәкләтә сатыла, җибәрелә торган. *Кисәкле товарлар.*

КИСӘКЛӘП *рәв.* Кисәк-кисәк итеп, кисәкләргә бүлеп. *Алма турыйм, алма турыйм, Алма турыйм кисәкләп.* Җыр.

КИСӘКЛӘТӘ *рәв.* **1.** Кисәге белән. *— Эш белән генә ул чаклы мал таба алу бик авыр хәл... Кисәкләтә алтын табып, хуҗаңа бирми калдыргансыңдыр, — диләр [миңа].* Г. Ибраһимов.

2. Кисәкле килеш, вакламыйча. *Кисәкләтә алу. Кисәкләтә сату.*

КИСӘКЛӘҮ *ф.* Вак кисәкләргә, өлешләргә бүлү; кисәк-кисәк итеп аеру.

КИ'СӘКТӘН *рәв. сөйл.* Кинәт, көтмәгәндә. *Кисәктән йөзгә бернәрсә тиеп китте.* Г. Тукай. *Кисәктән генә [Гәрәйнең] күңеленә шик төште.* С. Сабиров.

КИСӘКЧЕК *и.* **1.** *Кеч. дәр. к.* кисәк I (1—3 мәгъ.).

2. Нинди дә булса матдә массасының состав өлеше булган, күзгә күренмәслек яки чак кына күренерлек бик вак бөртек. *Кисәкчекләрнең чәчелүе. Электр кисәкчекләре. Кисәкчекләрне тизләтүче механизмнәр.*

КИСӘКЧӘ' *и.* **1.** *к.* кисәкчек 1. *Шактый көчле җил, тыкрык араларында буталып, әре генә кар кисәкчәләрен төрле якка очыргалап йөртә.* Ш. Камал.

2. *к.* кисәкчек 2. *Корылмалы кисәкчә.*

3. *лингв.* Аерым сүзләрнең, сүз тезмәләренең яки җөмләләрнең эчтәлегенә нинди дә булса мәгънә төсмере кертә торган ярдәмлек сүз (мәсәлән: **бит, ич, ук-үк, лабаса-ләбаса** һ. б.).

КИСӘ'КЧӘ *рәв.* Тулысынча түгел, өлешчә.

КИСӘТМӘ *с.* Кисәтү характерындагы. *Кисәтмә сигнал. Кисәтмә төс. Кисәтмә диктант.*

КИСӘТҮ *ф.* **1.** Алдан белдерү, искәртү, әйтү. *Финнарга кадәр дүрт йөз, биш йөз метрдан да артык түгел, дип кисәттеләр.* Г. Әпсәләмов. *— Алдан кисәтеп куям: юк-бар сөйләп вакытны алмагыз.* Н. Фәттах. *Машина, --- кисәтү гудогы бирә-бирә, күпер аша чыгып китте.* Г. Гобәй.

2. Алдан күрелгән чаралар ярдәмендә нәрсәне дә булса булдырмау. *Йогышлы авыруларны кисәтү. Су басуны кисәтү.*

3. *и. мәгъ.* Күрсәтмә; шелтә. *— Мин сезгә ялгышларыгыз турында күп мәртәбәләр кисәтү ясадым.* Р. Ишморат. *— Мин ун ел --- эшлим, бер тапкыр кисәтү дә алганым юк.* Г. Ахунов.

КИСӘТҮЛЕ *с.* Кисәтү белдергән. *Касыйм Хәйдәрнең кисәтүле чыраен күргәч сагайды.* Г. Минский. *Ашкынулы, өндәүле һәм кисәтүле музыка яңгыра[ды].* Р. Төхфәтуллин.

КИСӘҮ I *и.* **1.** Күмерләнеп янып торган яки күмерләнеп сүнгән утын, агач кисәге. *Зөлфә көйрәп-пыскып яткан кисәү һәм утлы күмерләр өстенә иң әүвәл коры ботаклар салды.* Э. Касыймов. — *Утын чи булгач, тиз янмый шул, абыстай. Кисәве кала. Кисәве янып беткәнче көтсәң, күмере бетә.* К. Әмири.

2. *диал. к.* кисәү агачы. *Кисәү сабы озын булса, кулың көймәс.* Мәкаль.

Кисәү агачы — мичтәге ягулыкны болгату, утлы күмер алу өчен тимердән башы бөгеп эшләнгән озын саплы җайланма. *Кулына кисәү агачы тотып мич актара торган Гөлбаһар абыстай --- оялып, алъяпкыч аша гына [кунакларга кулларын] суздыы.* М. Гали. **Кисәү башы** — *к.* кисәү I (1 мәгъ.). *Авыл урамнарында буш тартмалардай утырып калган кирпеч стеналар, --- көйрәгән кисәү башлары гына.* А. Расих.

КИСӘҮ II: **кисәү гөмбәсе** — башаклы үсемлекләрдә йогышлы авыру тудыра торган паразит гөмбә. *Кисәү гөмбәсе белән зарарланган ашлыкларның чәчәк төркемнәре, көйгән кисәү кебек, кап-кара, вак споралар белән капланалар.* Ботаника.

КИСӘҮЛӘНҮ *ф. сир.* Кисәүгә I (1 мәгъ.) әйләнү. *Кисәүләнеп сүнгән авылларга Керми үтәм, Чөнки алар мина кырларыннан Куркыныч һәм хәтәррәк.* Соц. Тат.

КИСҮ *ф.* **1.** Берәр үткен әйбер белән нәрсәне дә булса кисәкләргә бүлү, өзү, тураклау; бөтеннән бер кисәк аерып алу. *Пыяла кисү. Пычкы белән кисү. Токмач кисү.* □ [*Бәлешләрнең*] *берсен Нәгыймә карчык көндезге чәй янына кисте.* Ш. Камал. *Бер төркем халык --- зинданга һөжүм итте ләр, телефон чыбыкларын кистеләр.* Г. Ибраһимов. [*Газинур*] *гимнастерка кесәсеннән --- Матросовның газетадан кисеп алган рәсемен чыгарды.* Г. Әпсәләмов. || Кыскарту (чәч, сакал һ. б. турында). — *Бусы [шәһәрдән килгән хатын] чәчен кисмәгән икән, теге вакыт килгәне кискән иде.* А. Шамов. *Пөхтә итеп кискән түгәрәк сакал --- аңа аеруча матурлык биреп тора.* Р. Ишморат.

2. Өс яки аяк киеме тегү өчен тукыма, күн яки мехны билгеле бер өлгедәге һәм үлчәүдәге кисәкләргә бүлү. [*Низами карт*], *сәкегә кәгазь өлге салып, --- бүрек тышлыгы кисә.* М. Гали. *Киемне кешесенә карап кисәләр.* Мәкаль.

3. Операция юлы белән кешенең организмының берәр зарарланган кисәген аерып алу. *Әти, фронтта каты яраланып, Уфа шәһәрендә госпитальдә ятуы турында язган иде. Җитмәсә, уң аягын тездән югарыдан кисеп үк алганнар.* Э. Касыймов.

4. Үткен әйбер белән тәнне җәрәхәтләү, яралау. *Җаныем, урак урган чакта Кулың кисмә — кан агар.* Г. Тукай.

5. Икегә аеру, бүлү (юл салып, ерып). *Таш тауларны, урманнарны кисеп, Ерак киткән поезд юллары.* Ф. Кәрим. *Авылны уртага кисеп чыккан Карамалы инеше янында салкын чишмә ага.* Х. Садрый. || Хәрәкәт белән яру, ярып үтү (суны, һаваны). *Безнең пароход күкрәге белән зәңгәр диңгез өстен туктаусыз кисә.* Сов. әд. || *күч.* Тавыш дулкыннарының һавада таралуы турында. *Кайдадыр бер малайның кычкырган саф, нечкә тавышы һаваны кисеп үтте.* Н. Исәнбәт.

6. Ызанлап, буразналап аеру, бүлү (җир участогы турында). — *Менә юлар, дәүләт кисеп биргән җир өчен әллә миңа үпкә саклап йөрисеңме?* М. Шабай. *Хасиятулла --- бер буразна чамасы тегенең җирен кисте дә алды.* Ш. Камал.

7. Ватып, кисәкләргә бүлеп казып чыгару; хәзерләү (ташны, ташкүмерне). *Ташкүмерне без кисәбез, Кемнәр ала исәбен.* Җыр. *Җиһанша карт: — Без егет чакта Уралда таш кистек, — дип мактанып сөйли иде.* Г. Ибраһимов. || Төзү материалы буларак агач хәзерләү турында. *Агач кисү.* □ *Петр патша пароходлар ясаткан, шуңа күрә бөтен ил белән урман кискәннәр.* Г. Әпсәләмов.

8. Берәр төрле эшне, сөйләүне һ. б. бүлдерү, туктату, өзү. *Хәят кергәч, Рокыя сүзен кисте.* Ф. Әмирхан. *Мылтык тавышы кисте карт ананың Йөрәгеннән чыккан каргышны.* М. Җәлил. || *күч.* Эшнең нормаль барышына комачаулау, вакытында үтәлүенә тоткарлык ясау. *Прогулчылар — безнең дошман, Эш планын кисәләр.* М. Крыймов.

9. *күч.* Кыскарту, киметү, азайту. *Штатны кисү. Хезмәт хакын кисү. Хокукларны кисү.* □ *Үлчәп карагач, Дәүләтҗанның таушалып беткән дәфтәренә язып куелган йөз илле центнер урынына йөз генә центнер көл чыккан. Менә шуның өчен аның 25 хезмәт көнен кистеләр.* Р. Шәфигуллин.

10. *күч.* Кыйнау. *Әй кистек без Деникинны, Поляк паннарын!* Ф. Кәрим. — *Кагылып кына кара! Биллаһи дип әйтәм, җаныңны алганчы кисәрмен үзеңне.* М. Хәсәнов. || Җәзалау, үтерү. *Фашистларда — талау, асу, кисү; Бездә — тормыш, бездә — матурлык.* Ә. Ерикәй. *Ант иткән ул, партизанка, Дошманнарны кисәргә.* Г. Кутуй.

11. *күч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса юлына аркылы төшеп, алга таба хәрәкәт итүенә тоткарлык ясау, кыенлык тудыру. *Немецларның һәм финнарның берләшкән төньяк группа гаскәрләренең төп бурычы әнә шул Киров магистрален кисү иде.* Г. Әпсәләмов. [*Эшелонда баручы*] *тоткыннар арасында, кызыллар юлны менә кисәрләр, менә кисәрләр, дигән өмет көчәйде.* И. Туктар.

12. *күч.* Үткен нәрсә белән кискәндәге сыман авырту барлыкка китерү, әз калдыру. *Иңбашын кисә капчык бавы.* Ф. Кәрим. *Чиләк бавы кулны кисә, кайтакайта [Сәлимнең] беләге өзелеп төшеп калган кебек була.* Ф. Хөсни. *Яхшы атның башын нукта кисәр.* Мәкаль. || Кискен, ачы җилнең битне куыруы турында. *Җил кисү аркасында, [Әмирҗанның] бите бакыр төсенә кереп җыерчыкланган.* Ш. Камал. *Суык җилләр исте, Йөзне кисте.* Г. Афзал. || Чагылдыру, камаштыру (күзләрне). *Көмеш кенә йөзек алтын каш — карасам да күзләрем кисә.* Г. Тукай. *Күзне кисми торган тоныкъ кына яктылык лампа тирәсенә генә таралган.* Л. Ихсанова.

13. *күч.* Бетерү, юкка чыгару (ышанычны, өметне һ. б.). *Матур тормыш, якты көн күрүдән Өметләрен тәмам кискәннәр.* М. Гафури. — *И нәгъләт кыз. Үз ризыгыңны үзең кистең.* М. Фәйзи.

14. *күч.* Кискен һәм ачык, артык бәхәсләшергә урын калдырмаслык итеп әйтү. *Мин аңа туп-туры кистем: син, дидем, тугры сүзгә колак сал, дидем.* Г. Ибраһимов.

◇ **Кисеп ташлаган (кискән) тырнагына да тормау** (кешегә карата) — тиң булмау, күп түбән булу. — *Гөлҗиһан ул Сәлимә туганымның кисеп ташлаган тырнагына да торырлык түгел.* Г. Камал. — *Килер бер көн, без синең белән аның кискән тырнагына да тормабыз.* Г. Галиев. **Кисеп әйтү** — ачык итеп, өзеп әйтү. — *Хәзергә ул турыда кисеп үк әйтә алмыйм.* Ш. Камал.

КИСҮЧЕ *и.* Кием тегү өчен тукыма, күн һ. б. ларны билгеле бер өлгедә кисеп бирүче эшче, оста. *Мастер кисүчеләрдән тегүчеләргә постау ташып йөри*

торган --- бер кыз бала белән сөйләшеп тора иде. А. Расих.

КИТ *и. зоол.* Диңгез һәм океаннарда яши торган, гәүдә төзелеше белән балыкка охшашлы имезүче зур хайван. *Гренландия киты. Зәңгәр кит.* □ *Китлар, мыеклары арасыннан диңгез суын сөзеп, --- көтүләре белән океан киңлекләрендә йөзеп йөриләр.* Р. Мостафин.

КИТАБИ *с.* Язма әдәби тел өчен генә хас, җанлы сөйләү теле өчен характерлы булмаган. *Китаби сүз. Китаби стиль.*

КИТА'ЙКА *и.* 1. Салкынга чыдамлы алмагач сорты. *Ишеткәнең бармы: салкыннарга Түзмәгәндә калын имәннәр, Алтын китайкалар исән калып, Җәен тагын алма биргәннәр.* С. Хәким.

2. Шул алмагачның вак җимеше, алмасы.

КИТАП *и.* 1. Нинди дә булса текстны эченә алган, битләре билгеле бер тәртиптә бергә җыйналып төпләнгән басма (элек — шулай ук кулъязма) әсәр. *Китап бастыру.* □ *Кечкенә кулдагы 64 битле бу китапта хәзерге чорга характерлы бер күренеш чагылдырылган.* М. Җәлил. *Китап укысаң, белемең артыр, Укымасаң, белгәнең дә онытылыр.* Мәкаль. || Бастыру өчен язылган яки аерым басма итеп чыгарылган зур гына күләмле нинди дә булса әсәр. *Матбугатта мактап телгә алуларга карамастан, мин китап чыгу белән үземдә тирән канәгатьсезлек сизендем.* Г. Ибраһимов. *— Газета-журналлар минем шигырьләремне яратып басалар. Басылып чыккан китапларым да бар.* Х. Садрый.

2. Әдәби әсәрнең зур кисәге. *Романның беренче китабы шагыйрьнең бала чагыннан башлана.* Ә. Еники.

3. *күч.* Китапның (1 мәгъ.) акыл өйрәтә торган, тирән, дөрес фикер тупланган авторитетлы чыганак булуына ишарә итеп әйтелә. *Китап әйтә: үзеңнән түбәннәргә карап шөкер ит, югарыларга карап фикер ит.* Ш. Камал. *Һәркем үз юлында: сатучы хисап сөйли, укытучы китап сөйли.* Мәкаль.

Китап корты — 1) *зоол.* үлән ашаучылар семьялыгыннан иске кәгазьләр, китаплар арасында яши, үрчи торган бөҗәк; 2) *күч, ирон.* китап сөюче, китаплар белән артык мавыгучы. *— Без бит филологлар, китап корты безнең халык.* Г. Ахунов. **Китап сүзе** — 1) язма әдәби телдә генә кулланыла торган сүз, тәгъбир. *Биектау мулласында озак еллар хезмәткә йөргәнгә, ул аннан әллә нинди китап сүзләре отып алган.* М. Гали; 2) китап (3 мәгъ.) өйрәткән акыллы киңәш, файдалы фикер. *Лампа төбендә Тыңлыйлар китап сүзен. Бүлмә тын.* Х. Туфан. [*Ситдикъ Габдуллага:*] *Укымышлы малай икән син. Китап сүзен бик яхшы беләсең икән.* Ә. Фәйзи. **Китап теле** — язма әдәби тел. *Китап теле белән сөйләү.*

◇ **Китапта язылмый торган сүз** — әшәке, әдәпсез сүз. *Көтүче Кузьма --- [кәҗәләрне] бер дә китапта язылмый торган сүзләр белән сүгә.* Ш. Камал.

КИТАПТАГЫ'ЧА *рәв.* Китапта язылганча. *Мин сезне киенеп-ясанып бакчага чыккан яки театрга барган чагыгызда гына күргән һәм, китаптагыча, бер күрүдә гашыйк булып акылын җуйган кыз түгел.* М. Әмир.

КИТАПХАНӘ *и.* 1. Җәмәгать тәртибендә файдалану өчен китап, журнал, газета һ. б. үзендә туплый һәм саклый торган учреждение. *Фәнни китапханә. Шәһәр китапханәсе.* □ *Пионерлар, уку йортында, мәктәп китапханәсендә иген үстерүгә карата нинди китап, журнал бар — алып кайтып, мул уңышка ирешүнең серен өйрәнделәр.* Г. Гобәй. || Шул учреждение урнашкан бина яки махсус бүлмә. *Китапханә ачылды.* Һ. Такташ.

2. Аерым бер кеше тарафыннан уку, фәнни һ. б. эшләр өчен сайлап тупланган китаплар җыелмасы. *Китапханәне кешеләр гомер буе җыялар. Ай саен бер китап алганда да берничә ел эчендә үзең карап туймаслык китапханә оештырып була.* Н. Дәүли. || 3. Эчтәлеге белән берәр өлкәгә караган яки укучыларның аерым категориясе өчен чыгарылган китаплар сериясенең атамасы. *Балалар китапханәсе. Дингә каршы китапханә.*

КИТАПХАНӘ'ЧЕ *и.* Китапханәләр арасында башкарыла, алып барыла торган. *Китапханәара абонемент.*

КИТАПХАНӘЧЕ *и.* Китапханәгә алынган китапларны тәртипкә китерү, саклау һәм аларны укучыларга бирү эшен башкаручы хезмәткәр. *— Ичмасам, булдырды Гөлфия. Акбалыкта укып, китапханәче булды.* Э. Касыймов.

КИТА'ПЧА *рәв.* 1. Китапта язылганча, китап сүзләре белән; матур итеп. [*Фәтхерахман*] *китапча сөйләргә ярата.* Г. Әпсәләмов. [*Рифат*], *матур әдәбиятны кычкырып укып, китапча тезеп сөйләргә өйрәнгән инде.* Н. Исәнбәт. || *с. мәгъ.* Китап теленә хас, китапта язылган. *— Безнең кебек надан кеше китапча сүзләрне дөрес әйтә алмас инде, балам, — диде Сәлим бабай.* М. Гафури.

2. *и. мәгъ.* Дини китапны язылганча укый һәм яттан сөйли алу сәләте турында. *— Китапчага да бик шәп ул [Насыйр], — диде Тимербай. — Урысчасын --- Хөсәен абзасы укытты. Китапчасын Казан мәдрәсәсендә укыды.* М. Гали.

КИТАПЧАЛАП, КИТАПЧАЛАТЫП *рәв. к.* китапча 1. *Акыллы бер колхозчы үз хуҗалыгын --- оста итеп, бәрәкәтле итеп, китапчалап әйткәндә, рациональ итеп оештыра алган икән, моның ни гаебе бар?* Р. Төхфәтуллин. *Хәзрәтнең әле бер кодага, әле икенчесенә китапчалатып зерә дә мәзәк сүзләр әйтүе ишектән дә, ачык тәрәзәләрдән дә гел ишетелеп торды.* Г. Бәширов.

КИТАПЧЫ *и. иск.* 1. Китап бастырып чыгаручы, нәшрият тотучы. *Китапчыларыбыз бу елларда, бер-берсеннән уздырып, --- мәктәп китапларын нәшер итәргә тотындылар.* Ф. Әмирхан. *Әлбәттә, китап басу һәм сату китапчыларга табыш та китергән.* Э. Кәримуллин.

2. Китап белән сәүдә итүче, китап сатучы. *Ул көнне Казан китапчылары бер тиен дә сату итә алмыйча, авызларын салындырып, өйләренә кайттылар.* Г. Тукай.

КИТАПЧЫЛЫК *и. сир.* Китап язу, бастырып чыгару яки сату эше. [*Шушы*] *көннәрдә китапчылык галәмендә ике гүзәл әсәр күзгә күренде.* Г. Камал. *Егерменче йөз башында китапчылык мәйданында да яңага таба омтылыш башлана.* И. Рәмиев. || *с. мәгъ. лингв.* Китап теле стиленә хас. *Җөмләнең хәбәре составында гына килә торган „гыйбарәт", „тәшкил" кебек сүзләрдән китапчылык исе аңкый.* С. Фәйзуллин.

КИТЕК *и.* 1. Берәр нәрсәдән кителеп, ватылып төшкән кыйпылчык, вак кисәк. *Айсберг китекләре.* □ *Снаряд китекләре һәм пулялар белән телгәләнгән агачлар әле бөреләнмәгәннәр.* Г. Әпсәләмов. *Искәндәр, бер сүз дә әйтмичә, чынаяк китеген алып күзләренә китерде.* Г. Гобәй.

2. *сөйл.* Берәр мәйданның, кишәрлекнең почмагы, почмакланып чыгып торган җире. *Болынның чабылмый калган китекләре.*

3. Кителеп калган урын, уенты. *Балта йөзендә вак китекләр барлыкка килү.* || Борын, ирен һәм колакта шундый уенты. *Ирен китеге. Сарык колагына тамга итеп салынган китек.*

4. *күч.* Кимчелек, җитешсез як. *Җырның ертыгы юк, көйнең китеге юк.* Мәкаль.

5. *с. мәгъ.* Китеге (3 мәгъ.) булган, кителгән. *Китек ирен. Китек колак. Китек чүлмәк.* □ *Яхшы кеше— көмеш кашык, яман кеше — китек кашык.* Мәкаль. *Кирәкмәгән китек балта боз чабарга яраган.* Мәкаль. || Почмаклап киселгән, почмаклап уеп алынган. [*Зыяның*] *өстендә китек якалы кыска бишмәт белән тар гына чалбар.* Х. Садрый. || *күч.* Төшенке, боек. *Китек кәеф белән йөрү.* □ *Китек күңел үкенә дә башлый.* Г. Бәширов.

6. *хәб, функ. күч.* Кимчелекле, җитешсез; канәгатьләнерлек түгел. *Җиһан сизә үзен бәхетле итеп. Тик шулай да --- аның бәхетенең бер ягы китек.* М. Җәлил. — *Тормышыбыз да яхшы. Тик бер чите генә китек — балабыз юк.* Г. Минский.

КИТЕКЛЕК *и.* 1. Китек (3 мәгъ.) булу. [*Газизнең*] *борыны китеклек хәзер минем өчен әһәмиятен югалткан иде.* Ш. Камал.

2. *күч.* Кимчелек, җитешсезлек; канәгатьсезлек. *Ул көннәрдә аның шәхси тормышында да бернинди китеклек юк кебек иде.* М. Әмир. *Минем бу бәхетлелек, үз-үземнән ризалык тойгымда ниндидер бер китеклек, җитешмәгәнлек сизелә башлады.* Ф. Әмирхан.

КИТЕКЛӘНҮ *ф.* 1. Китек хәлгә килү. *Чалгы йөзе китекләнү.*

2. *күч.* Начарлану, кире якка үзгәрү. [*Кашшафның*] *бая бакчага килеп керү белән туган соклану хисе, белмим, нигәдер китекләнә бара иде.* Р. Төхфәтуллин.

КИТЕКЛӘҮ *ф. сөйл.* 1. Китеп алу, китеп төшерү.

2. *күч.* Кимчелекле итү; ямьсезләү. *Ишек алдына чыгуга Кашшаф йорт-җирнең бөтенлеген китекләп торучы яртылаш җимерек бурабзарга игътибар итте.* Р. Төхфәтуллин.

КИТЕК-МИТЕК *с. сөйл.* Кителгән, ярылган (савыт-сабага карата). *Китек-митек чынаяклар да, ләббәйкә дигән кебек, үзләренә чәй коелуны көтәләр.* Ш. Камал.

КИТЕЛЬ *и.* Утырма якалы, бер генә якка капланмалы пиджак—форма киеме. [*Капитанның*] *җиңнәренә алтын укалы тасмалар тегелгән куе зәңгәр төстәге кителе гәүдәсенә ятышып тора.* Р. Мостафин.

КИТЕЛҮ I *з-сыз ф. к.* китү I (1, 21 мәгъ.). *Ерак кителгән.* □ *Бая әниең бәлеш төбе ашаткан иде, сусап та кителде.* М. Фәйзи.

КИТЕЛҮ II *ф.* Ватылып, кыйпылып төшү. *Чапма ташка, балтаң кителер.* Мәкаль. *Пыяла керт иттереп кителгәч кенә һади җиңел сулады.* А. Гыйләҗев. *Еллар узудан --- таш йортларның штукатурлары кубып төшкән, почмаклары кителгән.* Г. Әпсәләмов.

КИТЕМ *и. сөйл.* Чыгым, сарыф ителә, тотыла торган нәрсә. *Килемен баксаң — игез-игез, Китемен баксаң — сигез-сигез.* Н. Исәнбәт.

КИТЕРҮ *ф.* 1. Кулда тотып, күтәреп алып килү. *Газизә ут яндырып китерде.* Ш. Камал. *Ул арада өстәл өстенә кайнар чәй дә китереп куйдылар.* А. Шамов. || Берәр төрле транспортта (атта, машинада, самолетта һ. б.) алып килү. *Менә бүген дә безгә, берничә санитар автомашинасына төяп, яралыларны китерделәр.* Ә. Айдар. || Ияртеп, юл күрсәтеп яки атка, машинага һ. б. утыртып алып килү. — [*Сиражетдинне*] *Хәмидуллалар җитәкләп китерделәр.* Г. Камал. *Акбай үзе артыннан иярган кешеләрне менә шул биек ярлы Яманкүлгә китерде.* Г. Ибраһимов. [*Хәсән*] *үзен китергән ямщикның комсызлыгы турында уйлады да үз-үзен шелтәләде.* Ф. Әмирхан. || Бер урыннан икенче урынга ташу (дәвамлы, кабатлаулы эшне белдергәндә). — *Нәсимә --- тау астындагы чишмәдән су китерәдер.* Г. Бәширов. || Алып кайту. *Шәһәрдән магазинга товар китерү.* □ — *Менә, әткәй, яңа газеталар китердем.* Т. Гыйззәт. || Куып алып килү, тарату (су, җил хәрәкәтләре белән). *Күңелле генә салкынча җил исте, баш, миләрне рәхәтләндерә торган тәмле яңгыр исләре китерде.* Ш. Камал.

2. Кайдан да булса кайтып, килеп, нинди дә булса яңалык әйтү, сөйләү. *Бу күңелсез хәбәрне авылга Газзән китерде.* Г. Әпсәләмов. [*Йосыф:*] *Ач әле, әптерәй туган!.. Урмандагылардан хәбәр китердем.* К. Нәҗми. || Газета, радио, телеграф аша хәбәр белдерү, тапшыру турында. *Газеталар көн саен яңа хәбәрләр китереп тору.* □ *Икенче көнне билгеләнгән вакытка телеграф аппараты хәбәр китерде.* Ш. Усманов.

3. Нәрсәгә дә булса якынлаштыру, якын итеп кую. [*Хәлим*] *суык суны кызылармеецның иреннәренә китерде.* Г. Гобәй. [*Эш көтүчеләр*], *салкынлыкка чыдый алмагач, --- кулларын, бер-берсенә китереп, җиңнәре эченә тыгып куйганнар.* М. Гафури. || Кемнәрсә тирәсенә килергә рөхсәт, ирек, мөмкинлек бирү. [*Шәйдүк карт*], *склад тирәсенә һичбер җан иясен якын китермичә, як-ягына каранып тик утыра.* К. Нәҗми. [*Закир:*] *Хәзер минем акчам беткәч, минем урыныма өеңә икенче кешеләр китерә башладыңмыни?* Г. Камал.

4. Кая да булса бару өчен юл хезмәтен үтәү, берәр нәрсә янына юл күрсәтү, алып чыгу.

5. Берәр төрле сәбәп аркасында кая да булса килергә мәҗбүр булу. [*Исмәгыйль:*] *Мине монда --- Галиябануны Хәлилдән көнләү китерә. Көнләү генә дә түгел, курку китерә.* М. Фәйзи. *Чех сугышы мине бу якка китерде.* Г. Ибраһимов. || Нинди дә булса (карарга, фикергә) килергә мәҗбүр итү, этәрү.

6. Берәр төрле максат белән чакыртып алу, чакырып алып килү. *Уфадан Җамалетдин исемле берәүне яшь мулла итеп китергәннәр иде.* М. Гафури. — [*Төхфәт*] *алга бармый. Кичә дә, бүген дә доктор китереп караттык.* Ш. Камал. || Кемне дә булса ияртеп алып кайту. *Килен итеп китерәсең Монда Бибкәй туташны.* Н. Исәнбәт.

7. Берәр нәрсәнең сәбәпчесе булу, нәрсә дә булса бирү, бар итү (нәтиҗә буларак). *Азатлык китерү. Шатлык китерү. Кимчелек китерү.* □ *Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш.* Г. Тукай. [*Артамонов:*] *Мин фронттта, солдатлар арасында күбрәк файда китерермен.* Т. Гыйззәт.

8. *сөйл.* Тудыру (кешеләр һәм хайваннар турында). *Уңган хатын ул китерер, Изге хатын кыз китерер.* Мәкаль. *Сарык ике бәрән китерде.* Г. Бәширов.

9. „Дөньяга“, „мәйданга“ кебек сүзләр белән килгән тезмәдә: ижат итү, төзү. [*Тукайның җырлар ижат итү юлындагы эшчәнлеге*] *сатирик пародияләр мәйданга китерү --- сызыгы белән бара.* Г. Нигъмәти.

10. Нәрсәгә дә булса теләк тудыру, хис уяту. *Йокыны китерү.* □ *Дбинең --- үзенең башыннан үткән хәлләрен сөйләвең --- Хәмидәнең тыңлаган саен тыңлыйсын китерә.* М. Гафури. *Фатыйманың матур йөзендәге ачыклык һәм тавышындагы самимия Шакирга аны һәм дус, һәм якын итеп күрсәтә вә аның алдында йөрәктәге нәрсәләрне ачып ташлыйсын китерә иде.* Ф. Әмирхан.

11. Фикерне куәтләү, ныгыту, дәлилләү өчен нәрсәгә дә булса таяну, нәрсә дә булса өстәп әйтү. *Менә шул сүзләрне куәтләү өчен, монда бер мисал китерәмен.* Г. Тукай. — *Нәгыйм бабайлар мәкален урынсыз җирдә китерә.* Ш. Камал.

12. „Рәвешендә“, „ролендә“ һ. б. ш. сүзләр янында: куллану, файдалану. *Табигать сурәтләрен бирүне символ һәм параллелизм рәвешендә китерү „Яшь йөрәкләр“ романында --- күп кенә очрый.* Г. Нигъмәти.

13. Юнәлеш килешендәге исем белән килгән кайбер тезмәләрдә шул исем белдергән нәрсәне әшләү, шул нәрсәгә ия итүне белдерә. *Уртак ваклаучыга китерү. Тәртипкә китерү.* □ *Бу ташларны мондый ялтыравыклы хәлгә китерү ансат булмады.* Д. Аппакова. *Ниндидер көч аның аякларын хәрәкәткә китерде.* Г. Галиев. || Шул исем белдергән эш-хәлгә дучар итүне, билгеле бер нәтиҗә бирүне аңлата. *Зур уңышка китерү. Кире нәтиҗәгә китерү. Яңа ачышларга китерү.* □ [*Басыйров:*] *Ничек тыныч буласың, Николай Петрович! Имеш, заводны аварияга китер.* Р. Ишморат.

14. *күч.* Җиренә җиткереп үтәү, тиешле дәрәҗәдә башкару. *Уенның берәр шартын китерә алмаган кешегә җәза бирү.* □ *Җыр җырласаң, китереп җырла, Егет икәнлегең беленсен.* Җыр.

15. *боер. ф. форм.* **китер.** Нинди дә булса ярдәм, хезмәт күрсәтергә тәкъдим иткәндә әйтелә: „кая, я әле, бир әле, кил әле“ мәгънәсендә. *Бирче тарак. Китер, тарап алыйм, Мамык үскән менә башыңа.* Ш. Мөдәррис. [*Сөләйманов:*] *Яралангансың ич, китер, бәйлик.* И. Гази.

16. *рәв. мәгъ. күч.* **китереп.** Сугу, бәрү, төшерү кебек сүзләр алдыннан килеп, эшнең интенсив, бик кыска вакыт эчендә, көтмәгәндә башкарылуын белдерә. *Искәртмәстән китереп сугу..* □ *Хәйдәр көрәген дыңгырдатып җиргә китереп төшерде.* Г. Бәширов. *Д тән җиткәч, кинәт каты суык китереп бәргән.* Д. Аппакова.

17. *ярд. ф. функ.* 1) кайбер сүз төркемнәреннән тезмә фигыльләр ясап, „итү“ ярдәмче фигыле функциясен башкара. *Буржуйларны тар-мар китердек.* Н. Баян. — *Дер селкетеп, шау китереп туй итмәгәч, туймыни ул.* Г. Камал; 2) кайбер исемнәр янында шул исемнән фигыль ясый торган кушымча функциясен үти (мәсәлән: *хәтергә китерү — хәтерләү*). *Вакытында бу хат Хәятның бераз ачуын китергән иде.* Ф. Әмирхан.

◇ **Китереп кушу** — бергә җыеп, өстәп әйтү (әлек булганнарны). [*Рәгыя*] *инде баягы ызгышларны китереп куштың.* Г. Ибраһимов. **Китереп сугу** — һөҗүм итү. *Гитлерчыларның „Үзәк“ дип аталган армия группасы --- безнең Брянск фронты гаскәрләренә китереп сукты.* Г. Әпсәләмов. **Китереп терәү** — сүзне, фикер агышын, нинди дә булса эшне катлаулы, четерекле җирдә туктату, бүлү. [*Шәңгәрәй*] *сүзне шуңа китереп терәде дә, үзе белә торып, юри хата фикер әйтте.* Г. Ибраһимов. **Китереп чыгару** — 1) кая да булса берәр урынга алып килү; 2) урнаштырган яки яшереп куйган җирдән алу, алып күрсәтү; 3) ясау, барлыкка китерү. [*Малай кардан*], *зуррак кисәкләрне кирпеч өйгән кебек өеп, солдатка охшаган бер фигура китереп чыгарды.* К. Нәҗми; 4) *күч.* булдыру, берәр хәл тудыру. *Шулай итеп, хуҗалыктагы көрәш сәяси көрәш белән бәйләнә, сәяси көрәш кызып, тыныч тору дәверенең канлы корбаннарын китереп чыгаруга барып җитә.* Г. Нигъмәти; 5) *күч.* нинди дә булса эш, мәсьәлә турында искәртү, ишарәләү. — *Муллаларның билгеле инде: ахирәт ягын тартып, акча ягын китереп чыгаралар.* Ш. Камал.

КИТЕШ *и. сөйл.* **1.** Китү I (1 мәгъ.) фигыленнән ясалган исем. [*Михаил*] *Хәятның --- озын кара толымнарын селкетеп чабып китешен --- күз алдына китерергә тотынды.* Ф. Әмирхан. *Шушы китеш белән мин ике ел өйгә кайтмый йөрдем.* Ш. Камал.

2. *сир.* Үсеш. *Әдәбият ахшамы татар халкын хәзерге китеш өчен иң кирәкле булган китаплар илә таныштырачак.* Г. Тукай. *Башка укучылар Камилнең* [*укуда*] *мондый тизлек белән алга китешен игътибарсыз гына калдырмадылар.* М. Әмир.

КИТЕШЛИ *рәв. сөйл.* Кая да булса китеп барганда, китү уңаенда. *Китешли, бүгенгедәй хәтеремдә, әнисе озата чыкты.* Г. Ахунов.

КИТМӘН *и.* Агач сапка туры почмак ясап утыртылган көрәк сыман үткен эш коралы (җирне йомшарту, үсемлек төбенә туфрак өю, чүп үләннәрне тамырлары белән чыгару һ. б. өчен кулланыла). *Шау чәчәк атып утырган алмагач төбендә --- яшьрәк кенә бер кыз, китмәнен бер якка куеп, хат укып утыра.* Г. Бәширов. *Хәйләгә каршы хәйлә бар, Китмәнгә каршы кәйлә бар.* Мәкаль.

КИТМӘНЛӘҮ *ф.* **1.** Китмән белән эшкәртү (җирне). *Закир абыйсы арт бакчасында --- җир китмәнләп маташа.* Э. Касыймов.

2. *күч. сөйл. сир.* Күмү, җирләү (үлгән кешене). *Киткән кайта, китмәнләгән кайтмый.* Мәкаль.

КИТМӘНЧЕ *и.* Китмәнләү (1 мәгъ.) эше белән шөгыльләнүче. *Көннең көн буе кояшта янып каралган китмәнче, тубыктан су эчендә торып, бер түтәлдән икенчесенә күчә.* Г. Минский.

КИ'ТСӘНӘ, КИ'ТЧЕ *ы. мәгъ. к.* кит аннан. — *Өч йөз утыз [хезмәт көнен] ничек итеп тутырмак кирәк? Китсәнә, кит!* Г. Бәширов.

КИТӘН *и. иск.* Яхшы сыйфатлы җитен сүсеннән сугылган ак киндер тукыма. *Селкеп-селкеп чайкыйк җепне, Ап-ак булсын китәнең.* З. Байчурина. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Китән күлмәк киштәдә, киндер күлмәк киртәдә.* Мәкаль.

КИТӘРҮ *ф. сөйл.* **1.** Нәрсәдән дә булса тазарту, арындыру; бетерү (мәсәлән, киемдәге тапны). *Тапны китәрә торган сыекча.* || Бетерү, юк итү. — *Мин синең хафачылыгыңны китәреп, хәтереңне шатландырырмын.* К. Насыйри. *Җир йөзеннән мәңгелек Хәсрәт, газапларны китәр!!* Һ. Такташ.

2. Бозу, бетерү (ямен, матурлыгын). [*Кырмыскалар еланга:*] *Менә дигән кичәбезнең ямен китәрдең.* А. Алиш.

3. Алдыру, кырдыру (чәчне, сакал-мыекны). *Килер дә ул, кырып, такырлатып, Бабайларча, чәчең китәрер.* Ш. Мөдәррис. *Өс-башны алмаштырып, сакал-мыекны китәрсәм дә, билгеле, гаеткә бармадым.* М. Галәү.

КИТҮ I *ф.* **1.** Нинди дә булса урынны калдыру, кая да булса юнәлү, бару (җәяү яки берәр төрле транспортта). *Тимери, газетаны күтәреп, бригадирлары янына китте.* Г. Бәширов. [*Фатиха:*] *Юк, Шәйхелислам, мин җәяү генә китәрмен, якын бит.* А. Әхмәт. *Син бүген кичке поезд белән китәрсең.* Һ. Такташ. || Шул ук мәгънәдә, максатка ишарә итә. *Укырга китү. Ауга китү.* □ [*Исәнбай:*] *Әйдә, Байтирәк абый, безнең якка, Урал заводларына, эшкә китәбез.* Т. Гыйззәт. *Яшьләр аштан соң тирән елгага су керергә киттеләр.* Ш. Камал. || Хәрәкәт итү, күчү чаралары турында. *Пароход „Казан“ пристаненнан яңа гына кузгалып китте.* Р. Ишморат. || Күчмә кошларның җылы якка очулары турында. *Көз көне киткән бу кошлар яз көне тагын килә.* М. Гафури. || *күч.* Бату, чуму. *Су астына китүгә караганда, абынып-сөртенеп булса да, ярдан барганың яхшы.* И. Гази. *Йөзә белмәсәң, суга кермә, суга китеп үләрсең.* Мәкаль.

2. Таралу (дан, шөһрәт, сүз, хәбәр һ. б.). *Данлы Париж, Даның китте тарих буена.* Ф. Кәрим.

3. Каян да булса башлану. [*Авылның*] *аргы ягында әллә нинди яланнар китә.* Г. Ибраһимов. || Башланып көчәя бару, интенсив рәвештә дәвам итү (күп кешеләр катнашында үзара булган эш-хәл турында). *Ике арада көрәш китү.* □ *Сорашу китте, гәп куерды.* А. Әхмәт. *Сүз, гадәттәгечә, тормыш турында китте.* Х. Садрый.

4. Дәвам итү, сузылу (дәвамлы эш-хәл, күренешләр турында). *Бәхәс озакка китү.* □ *Сезнең белән безнең дуслык Китсен гомер буена.* Җыр. || Бару, дәвам итү (эш турында). — *Син әле эшеңнең ничек китәсен тәгаен белмәс͡борын* [*магазинына*] *кеше арттырырга да тотынгансың.* Ф. Әмирхан.

5. Билгеле бер вакыт чиге үтеп, алдагысы башлану турында. *Аның белән чынлап күрешә алмаганга ике ел тулып өченчегә китте дигәндә, быел тагын очраштык.* Г. Ибраһимов. *Сәгать икенчегә китте.* А. Әхмәт.

6. Агу, агып чыгу. *Ярадан кан китү.* □ *Нәгыймә карчыкның күзләреннән яшьләр китте.* Ш. Камал. || Агып таралу яки әреп юкка чыгу (язгы бозлар, кар турында). *Яз килер, Карлар эрер, Бозлар китәрләр.* Һ. Такташ. *Кары киткән кырлар, уҗымнардан Хәбәр алып исеп килә җил.* Х. Туфан. || Берәр нәрсә аркылы үтеп керү (чыгу), саркып, тамып тору (сыеклыклар турында). *Кибән эченә су китү. Түшәмнән су китү.*

7. Бетү, җуелу, юкка чыгу. *Төсе китү. Буявы китү.* □ *Кул ярасы китәр, тел ярасы китмәс.* Мәкаль. || Бетү, кимү. *Егәр китү.* □ [*Әбинең*], *кулаяклары сызлап, хәле китеп тора.* Ә. Еники.

8. Нәрсәгә дә булса яки нәрсә дә булса эшләү өчен билгеләнү, файдалану, ярау. *Дөянең ите һәм сөте азыкка китү.* □ *Без кисә торган утынның күбесе хәрби паровозларны йөртергә китә.* Г. Гобәй.

9. Тотылу, сарыф ителү. *Семьядагы шул кадәр сорыкортны кышлатсаң, азык* [*бал*] *күп китә.* А. Алиш. — *Болар бар да эшчеләр көче бит! Аларның файдасы эшләмәгән кешеләргә китә.* Х. Садрый.

10. Нинди дә булса эш, хезмәт урыныннан чыгу, нәрсә белән булса да шөгыльләнүдән туктау. *Заводтан китү. Бригадирлыктан китү.* □ — *Эш яратмаганга китми бит алар* [*эшчеләр*], *уңайлырак шартлар эзләп китә.* Г. Ахунов. || Юнәлеш килешендәге кайбер исемнәр белән килгәндә шул исемнән аңлашылган хәлгә күчүне белдерә. *Пенсиягә китү. Ялга китү.* □ — *Иртәгә, мин отпусткa киткәнче, башка нәрсәләр турында сөйләшербез.* Һ. Такташ.

11. Эш, профессия сайлауда, карашларда һ. б. ш. кемгә дә булса иярү, аның һөнәрен үзләштерү. *Большевиклар юлыннан китү.* □ *Балалар* [*нефтьче*] *этиләре эзеннән киттеләр, ә Филиппичның үзенә пенсиягә чыгарга вакыт җитә.* Соц. Тат.

12. Ясалу, эшләнү, җибәрелү (ялгышлык, хата һ. б.). *Ялгышлык китү.* □ *Корректорның игътибарсызлыгы аркасында афишада зур хата киткән.* Ш. Камал.

13. Үзгәрү, алмашыну (чырай, төс агару турында). *Никадәр караңгы булса да, мин аның чырае киткәнен күрдем.* С. Җәләл.

14. Тыела алмау, ирексездән дәвам иттерелү. — *Моны гомеремдә сөйләмәм дигән идем... Бер ачылгач, китте инде.* Г. Ибраһимов.

15. Гадәткә керү, модага әйләнү. *Ул чакта солдатлар арасында мыек йөртү киткән иде.* Г. Әпсәләмов.

16. Кем яки нәрсәсез калу, шулардан мәхрүм булу. *Кулаклардан батрак китте, Мулладан сәүдә китте.* Ш. Камал. *Алдашсаң — абруең китәр, Тиргәшсәң — кадерең китәр.* Мәкаль.

17. *күч.* Хәл итү өчен кая, кем-нәрсә карамагына җибәрелү, тапшырылу. *Эш судка киткән.* И. Гази.

18. *күч.* Үлү, һәлак булу. *Синең яланыңда әткәй китте аклар кулыннан.* Һ. Такташ.

19. *күч.* Саегу, суы кимү (елга, күл турында). *Агыйделкәй киткән, суы кипкән.* Җыр.

20. *боер. ф. форм., ы. мәгъ.* Гаҗәпләнүне, шикләнүне белдерү өчен кулланыла; *к.* кит аннан. — *Әллә елап йөри инде? Кит, юкка елама! Тапкан елар нәрсә!* М. Гафури. [*Әпипә:*] *Атакай гына!.. Карале боларны! Китче, кит! Ул тикле мин нишләгән?!* Г. Бәширов. || Юк, кирәк түгел. — *Кит, кит, риза була күрмә, кеше белән яман атлы булып бетәрсең.* Т. Гыйззәт. [*Хәнифә:*] *Кит, кит, укыйммы соң, фалнамә кадәр фалнамәне сиңнән мыскыл иттереп торыр хәлем юк.* Р. Ишморат.

21. *ярд. ф. функ.* 1) башлангыч урыннан яки сөйләүчедән нинди дә булса юнәлештә ераклашып башкарыла торган эш-хәлне белдерә. *Алар тагы Агыйдел уртасына кереп киттеләр.* Г. Гобәй. *Дилбегәләрне уйнатып, атка күңелле кычкырып, Гафиятне куып узып китте ул.* И. Гази; 2) үзеннән алдагы хәл фигыльдән аңлашылган сыйфатка күчү, шул сыйфатка артыграк дәрәҗәдә ия булуны белдерә. *Усалланып китү. Матурланып китү.* □ *Гыйлаҗи белән дуслашып киткәч, мин бу йортка бигрәк тә еш килә торган булдым.* Г. Ибраһимов. *Ул арада көн яхшырып китте.* Ш. Маннур; 3) юнәлеш килеш формасындагы кайбер исемнәр, сыйфатлар, рәвешләр янында килеп, шул сүздән аңлашылган сыйфатка, рәвешкә яки хәлгә күчүне белдерә торган тезмә фигыль ясый. *Уңайга китү. Авырга китү.* □ *Аңлата башласам, озакка китәр...* Ф. Хөсни. *Бер елны шулай җәен һавалар бик корыга китте.* М. Гали; 4) берәр төрле эш барышында яки сүз уңаенда шуңа бәйләнешле икенче бер эшне башкарып алу, үтәү. *Җавап биреп китү. Таныштырып китү.* □ *Сөйләгәннәргә әз генә йомгак ясап китәргә кирәк.* Г. Нигъмәти; 5) төп фигыльдән аңлашылган эшкә дәвамлылык төсмере өсти. *Санап китү.* □ *Карт йомшак украин теленда акрын гына, җайлап кына сөйләп китте.* Г. Бәширов; 6) эш-хәлнең кинәт, тиз башкарылуын аңлата. *Чатыр эче яктырып китте.* Г. Гобәй. — *Шулай итеп, акча ягыннан кысылды да китте кеше.* Ш. Камал; 7) нинди дә булса теләкнең, хиснең кинәт, көтмәгәндә барлыкка килүен белдерә. *Көләсе килеп китү. Ашыйсы килеп китү.* □ *Кинәт аның* [*Габдулланың*] *Кырлайга кайтасы, әтисен бик-бик күрәсе килеп китте.* Ә. Фәйзи; 8) төп фигыльдән аңлашылган эшнең булып үтүен белдерә. *Тәрәзә аркылы яшен шәүләләре чагылып китү.* □ *Кичкә таба бер аксыл болыт коеп явып китте.* Г. Галиев; 9) башлану төшенчәсен белдергән фигыльләр янында килгәндә башлануҗ хәленнән дәвамлылык хәленә күчүне аңлата. *Эшкә керешеп китү.* □ *Туган илебезне азат итү өчен искиткеч зур көрәш башланып китте.* Каз. утл.; 10) „булып“ ярдәмче фигыле янында килеп, эш-хәлнең кабатланып торуын, дәвамлы төс алуын белдерә. *Театрга еш йөри торган булып китү. Һәрнәрсәгә шикләнеп караучан булып китү.* □ *Низамый әледән-әле калага йөри торган булып китте.* М. Әмир; 11) *шарт ф. форм. -а* || *-ый* формалы хәл фигыль янында килеп, шул фигыльдән аңлашылган эш-хәлне дәвам иттерү мәгънәсен белдерә. *Саный китсәң, исемлек озынга сузыла.* Каз. утл.

Китеп бару — 1) китү, кая да булса юнәлү хәрәкәтенең күзәтелгән моментын белдерә. *Киек казлар китеп бара Мин күрмәгән илләргә.* Х. Туфан; 2) кисәк кенә, көтмәгәндә кая да булса китү. *Егет солдатка китеп барды.* А. Шамов. **Китеп йөрү** — озак вакытка кая да булса бару (эшкә һ. б. төрле максатлар белән). *Ераклларга китеп йөрим дә мин, Сагынып кайтам туган җиремне.* Ш. Маннур. — *Д син нишләп соң Кавказларга китеп йөрдең?* Ш. Камал.

◇ **Кит аннан, кит әле** — 1) шулаймы, дөресме (шатлыклы гаҗәпләнүне белдерә). — *Кит аннан, авылда торып, ничек инде без шәһәрнең иң кадерле кешеләре булыйк ди.* С. Рафиков. [*Гыйльметдин:*] *Чү, кыз-*

лар! — Кит әле! — Чынмы? Ф. Бурнаш; 2) булмас, кирәк түгел (бик нык гаҗәпләнү һәм ризасызлык хисләрен белдергәндә). [*Хәмидә:*] *Без сине өйләндермәкче булабыз. — Кит аннан, мин өйләнмим!* Г. Камал. **Киткән баш киткән** — *к.* беткән баш беткән.

КИТҮ II *ф.* Нәрсәнең дә булса бер кырыен, почмагын, очын кыеп алу, уеп төшерү. *Авыру ана --- [шоколадны] бераз китеп алды да баласына каптырды.* Г. Гобәй.

КИЧ *и.* **1.** Тәүлекнең көн бетеп, төн башлануга кадәр булган вакыт арасы. *Айлы кич.* □ *Акрын гына куера барган караңгылык иңә бүлмәгә, тик тәрәзәләрдә генә кышкы кичнең сыек яктысы саклана.* Ә. Еники. *Кичләрнең берсендә Хәят урнашкан семьяга ике гаскәри килеп керә.* Г. Кутуй. || Куну, йоклау сүзләре янында килгәндә „төн“ мәгънәсен белдерә. *Мин монда бер кич кундым.* М. Гафури. *Иртә иҫләремдә, кич төшемдә — насыйпмы әллә югыйсә.* Г. Тукай. || *күч. сир.* Нәрсәнең дә булса соңы, ахыры. *Игелекле эшнең киче юк.* Мәкаль.

2. *рәв. мәгъ.* Кичен, кич булгач. *Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас.* Мәкаль. — *Бүген кич актив җыелышы.* Р. Ишморат. || Соң. *Көн әле бик кич булмаса да, Гарифка төн кебек тоела иде.* Ш. Камал. [*Габдулла:*] *Безнең Сәлимә туташ көне буе өйдә булмый, кич кенә кайта.* Ф. Әмирхан.

Кич белән — кич (1 мәгъ.) җиткәч; *к.* кич 2. *Ана, кич белән тагын килергә булып, чыгып китте.* А. Шамов. *Кич белән кар ява башлады.* Г. Әпсәләмов. **Кич утыру** *этн.* — аулак йортка берәр төрле кул эше эшләп, күңел ачып утыру өчен жыелу. *Кызарып кояш байыйдыр, Матур кызлар яка кайыйдыр. Бер кайый да тагы бер сүтәдер, Кич утырган булып, егет көтәдер.* Җыр. **Кичкә калу** — кичегү, соңлау. — *Ярый, без кайтыйк инде, кичкә калдык.* М. Фәйзи. **Кичкә каршы (кырын), кичкә карап** — кич якынлашып килгәндә, кичкырын. *Берүзем дүрт ат белән кичкә каршы көлтәгә барырга булдым.* Г. Ибраһимов. — *Син кичкә карап нишләп йөрисең?* Ф. Бурнаш. *Исхак кичкә кырын гына Чаллыга килеп җитте.* А. Гыйләҗев. **Кичкә керү** — кич булу. *Кичкә керсәм, уйлана-уйлана таң аттыра алмый аптырап бетәм.* Х. Садрый.

КИЧЕГҮ *ф.* **1.** Соңгару, соңга калу, вакытына өлгерә алмау; тоткарлану. *Егет, хисе белән мавыгып, Бераз кичекте, ә паровоз көтмәде.* Ф. Кәрим. *Картның булган иң зур гөнаһсы: йомышка барган, шунда кичеккән.* М. Гафури. — *Хәлләр куркынычлы. Бер минут кичегергә ярамый.* Ш. Камал.

2. Кич булу, кич якынлашу (көн турында). *Көн кичегеп, караңгыланып килә иде инде.* М. Әмир.

КИЧЕГҮСЕЗ *рәв.* **1.** Билгеләнгән вакытка. *Җыелышка кичегүсез килеп җитү.*

2. Ашыгыч рәвештә, бернинди тоткарлыксыз. [*Операция өстәлендә*] *ярасы бик каты булган һәм һич кичегүсез хирургның катнашын сорый торган сугышчы ята.* Г. Әпсәләмов.

КИЧЕ'КМӘСТӘН *рәв.* Тиз арада, шунда ук, бернинди тоткарлыксыз. *Приказ үтәлгәч, миңа кичекмәстән хәбәр итәргә куштым.* Каз. утл. *Бу елларның яңа иҗтимагый тормыш, революцион көчләр алдына куйган таләпләре кичекмәстән әдәбияттa да чагылды.* Г. Нигъмәти.

КИЧЕКТЕРГЕСЕЗ, КИЧЕКТЕРМӘС *с.* Кичектерергә ярамый торган; тиз арада, бик тиз хәл итүне сорый торган. *Язучы-революционер урамнарда һәм мәйданнарда --- ялкынлы чыгышлар ясый, империалистик сугышны бетерергә чакыра, алпавыт җирләрен һич кичектергесез конфискацияләүне, бөтен власть-ны Советларга бирүне таләп итә.* Ман. Хәсәнов. *Ниндидер бер кичектермәс эше чыгып, сессиягә соңга калган председательне түземсезлек белән борчылып көткән кеше Нургали иде.* Ә. Еники.

КИЧЕКТЕРҮ *ф.* **1.** Билгеләнгән вакыттан икенче, соңгырак срокка күчерү. — *Болай булгач, утырышны кичектерергә туры килер инде.* Г. Бәширов. || Нинди дә булса эшнең үтәлү срогын озынайту, сузу. *Карт бай, --- ялынып барсаң, түләвеңне азрак кичектерә иде.* Г. Ибраһимов. — *Кыз җавап бирми. Җавап бирүен һаман кичектерә.* Р. Ишморат.

2. Тоткарлау. — *Сез үзегезнең сизгерлегегез белән минем эшне нәкъ ярты елга кичектердегез.* Г. Гобәй. *Безнең заманда картлыкны шактый кичектерергә мөмкин.* Азат хатын.

КИЧЕН *рәв.* Кич булгач, кич вакыты җиткәч. *Уракчысын көткән басуларга Мин моңаеп карыйм кичләрен.* Ә. Ерикәй. *Көндезен көн җылы, матур булуга карамастан, кичен суыта.* М. Гали.

КИЧЕН-КӨНДЕЗЕН *рәв.* Һәрвакыт, кичен дә, көндезен дә. [*Балалар*] *кичен-көндезен һаман бер тирәдә бутала торганнар иде.* Ә. Касыймов.

КИЧЕНҮ *ф.* **1.** Интегеп яшәү; кыенлык белән көн итү (ачлык, мохтаҗлык аркасында). [*Җаббар:*] *Сез мондагы җәмәгатьнең, авылдагы картлар, бала-чагаларның ничек киченүләрен яхшы беләсез.* Ф. Бурнаш. *Ярты кыштан соң, --- [Хәйретдингә] өяз земствосыннан бераз киченерлек стипендия бирелә башлый.* М. Гали. || Канәгатьләнү, риза булып яшәү. *Аз белән дә киченү.*

2. *и. мәгъ. сир.* Кичереш. *Җанлы кешене тойгысыз, эчке киченүсез биреп булмый. Ләкин ул тойгы, эчке кичену үзалдына бикләнгән ялгыз уйлану һәм януга кайтып калмасын.* М. Җәлил.

КИЧЕРЕНЕШ *и. сир. к.* кичереш. *Без биредә персонаж телен формалаштыру, лирик кичеренешләрне суртлау, диалектизмнарны урынлы куллана белү кебек бер-ике моментка гына тукталабыз.* Л. Җәләй.

КИЧЕРЕНҮ *ф. сир. к.* кичереш. *Бераздан шул уйларга, кичеренүләргә бүтәннәре кушылып, барысы бергә куера торгач, шуннан хикәя килеп туды.* Г. Бәширов.

КИЧЕРЕШ *и.* Кемнең дә булса көчле хис-тойгылар кичерүенә бәйләнешле рухи халәт. *Ана, улының тирән кичерешләрен күреп, тиз генә сүзне икенчегә борып җибарә.* Ә. Әхмәт. *Геройларның авыр кичерешләре турында укыганда, аның [Катяның] күзләре мөлдерәмә яшь белән тулы була.* Г. Әпсәләмов. *Эмоциональ кичереш көче һәр кешедә үзенчә була.* Х. Госман.

КИЧЕРЕШЛЕ *с.* Кичерешкә бирелгән, кичереш эчендә булган. *Мин Ленаның мондый кичерешле вакытын беренче тапкыр күрәм.* Ә. Баян.

КИЧЕРҮ I *ф.* **1.** Ярдәм итеп чыгару, күчерү, үткәрү (гадәттә елга аркылы, шулай ук үтүе кыен булган урыннардан). *Димче диңгез кичерә, дигәннәр борынгылар. --- Минем димчем диңгез түгел, авыл уртасындагы инеш аркылы да кичерә алмады.* А. Шамов.

2. Күрү, тату, баштан үткәрү (берәр төрле шатлык яки күңелсезлек, авырлык, авыру һ. б. ш.). *Нинди генә кыенлыклар кичерергә туры килмәсен, --- Нәфисә барысына да хәзер иде.* Г. Бәширов. *Кайгы кичерә бөтен халык.* Ә. Ерикәй. *Юл газабы — гүр газабы дигәннәр ич. Ә Исәнбайның кичергәннәре ашып та киткәндер, бәлки.* М. Шабай. || Нинди дә булса киеренке хәл эчендә булу, яшәү. — *Бөтен Россия хәзер шундый кискен сыйнфый көрәш чорын кичерә.* Т. Гыйззәт. *Әллә нинди, адәм баласына аңлашылмый торган бер сәер хәл кичерә ул.* И. Гази.

3. Берәр нәрсәгә дучар булып, юлыгып, аны җиңеп чыгу; шуңа түзү, чыдау. *Салкынны җиңел кичерү.*

4. Искә төшерү. *Уткәннәрне кичерә уйларыннан, Хәтерли Нәүл Кәган артларын.* Г. Хуҗиев. *Халисә онытылган хатирәләреңнең яңадан уянуын күңеленнән кичереп бара иде.* С. Рафиков.

5. *и. мәгъ. сир.* Кичереш. *Халитов үз тибының психологик кичерүләрен әсәрдәге идеягә буйсындырып бирми.* М. Җәлил.

КИЧЕРҮ II *ф.* 1. Гафу итү, гаепләмәү; җәзасыз калдыру. *Балалар шунда ук Разихның хыянәтен кичерделәр.* Ә. Фәйзи. *Елан - - - ялвара башлады: — Бер юлга инде кичерегез, азапламагыз.* А. Алиш. || *иск. дини.* Ярлыкау, гөнаһлардан йолу. [*Шәрәфи карт:*] *Башка вакыт әчмә, кирәге юк! Инде зарури булгач, ходай үзе кичерсә кирәк.* Ш. Камал.

2. *боер. ф. форм.* **кичер(егез).** Кереш сүз функциясендә кулланыла: гафу ит(егез). — *Кичерегез, күздә яшьләр тормый. Ләкин газапланып түгел.* һ. Такташ.

КИЧ-ИРТӘ *рәв. шигъ.* Кич белән һәм иртә белән (ягъни аулак, тыныч вакытларда). *Сагынып көтәм сине кич-иртә.* Җыр. *Күңелем эзли сине кич-иртә.* Ә. Ерикәй.

КИЧКЕ *с.* Кич (1 мәгъ.) белән була торган; кичкә мөнәсәбәтле. *Кичке җиләс һава. Кичке тынлык.* □ *Салмак кына җәелә кичке әңгер.* Ш. Мөдәррис. *Тәрәзәләрдән кичке кояш нурына күмелгән шәһәр күренә.* М. Маликова. || Кич белән эшли, хәрәкәт итә, чыга торган һ. б. ш. *Кичке смена. Кичке поезд.* □ *Нуруллин, кичке газеталарны сатып бетереп, сораучыларга юк дип кенә җавап бирә башлады.* А. Шамов. [*Сабир*] *кичке мәктәптә йөреп урта белем алды.* Каз. утл. || Кич өчен, кичәләрдә II (2 мәгъ.) кию өчен билгеләнгән. *Арттагы машинадан алтын күзлекле бер ир белән урта яшьләрдәге бер ханым төште. Хатынның өстендә кичке күлмәк.* Г. Әпсәләмов.

Кичке аш — 1) кич белән ашала торган соңгы ашау. *Бераздан - - - кичке аш башлана.* М. Гали; 2) кич белән ашау өчен билгеләнгән, хәзерләнгән ризык, ашамлык. *Галимә апа бүген кичке ашны да рәтләп ашамады.* М. Гафури.

КИЧКЕЛЕК *и. сөйл. к.* кичке аш 1. *Кичкелекне бик соң ашау.* □ *Нәсимә кичкелеккә аш-су әзерләгән.* Каз. утл.

КИЧКЕСЕН *рәв. диал. к.* кичен. *Урман каравылчысы кичкесен [бу кешегә] түбән өйгә урын җәзеп бирә.* Әкият.

КИЧКЫРЫН *рәв.* Кичкә таба, кич (1 мәгъ.) якынлашып килгәндә. *Кичкырын җил басылу.* □ *Кичкырын шау-гөр килеп авылга кайтып кергәндә, барысының да күңеле бик күтәренке иде.* И. Гази.

КИЧКӘ *рәв.* Кич белән, кичен. — *Кичкә театрга барабызмы әллә, апа?* Р. Ишморат. — [*Диләфрүз миңа*] *кичкә хат керттерер әле, бәлки.* Ф. Әмирхан.

КИЧКӘ'ЧӘ *рәв.* Кич булганчы, кичкә чаклы. *Өмет белән ышанмау кичкәчә сугыштылар.* Г. Ибраһимов. *Мөхәммәтҗан Сәйдәшев рәтләп редакциядә булмый, иртәдән кичкәчә газета өчен игъланнар - - - артыннан йөри.* З. Бәширн.

КИЧЛЕК *с.* Кичкә, төнгә җитәрлек. *Бер кичлек юл. Бер кичлек эш.*

◇ **Кичлеге юк** — кичке аштан соң озак утыра алмау (йокы, хәлсезлек басу һ. б. аркасында). [*Карчык:*] *Кызым, гаеп итмә инде, минем гел генә дә кичлегем юк. Әле менә янбашларым сызлап тора.* С. Рафиков.

КИЧЛЕКТӘ *рәв. сир.* Кич белән, кич җиткәч. *Ерак юллар үтеп, кичлектә Кояш ятмкан алтын бишеккә.* Ш. Маннур. *Кичлектә гадәттәге бәйрәм, уен-көлке, җыр, бию, мәхәббәт.* Ә. Баян.

КИЧЛӘП *рәв. к.* кичләтеп. *Истә әле: бервакытны кичләп кенә Кышкы юлда синең очка якынлаштык.* М. Җәлил.

КИЧЛӘТЕП *рәв.* Кич белән, кич җиткәч; соң гына. *Останково кешесе, Раузаларда чәй эчеп, кичләтеп юлга чыкты.* С. Рафиков. [*Сөнгать:*] *Кичләтеп кенә әллә кайдан кайта - - - абзый?* М. Фәйзи.

КИЧЛӘТҮ *ф.* 1. *к.* кичләү 1. *Көн кичләтә. Кыр өстенә, шәһәр өстенә караңгылык пәрдәсе акрын гына җәелә.* А. Шамов.

2. *сөйл. Йөкл. юн. к.* кичләү 2. *Кунакта дүрт кич кичләттеләр.*

КИЧЛӘҮ *ф.* 1. Кич якынлашу, кич җитү, кич булу. *Көн кичләп бара, алай да һава матур, күк шундый саф, аяз иде.* Н. Исәнбәт.

2. *сөйл.* Кайда да булса кич һәм төн уздыру, куну. *Фирдәвес күк, шул атауда алар кичли.* Аң.

КИЧТӘН *рәв.* 1. Кич белән, кичен. *Кичтән күк күкрәп бераз яңгыр да явып үткән иде.* Ш. Камал. *Кичтән башланган җил төне буе туктамады.* С. Рафиков.

2. Кичә кич белән, узган кич. *Алда, - - - кичтән шәп-шәрә калган җирдә, яшел ботаклардан әмәлләштерелгән шалаш кебегрәк ике-өч нәрсә күренә иде.* Г. Гобәй. *Кичтән яуган кар эреп беткән.* М. Шабай.

КИЧӘ I *рәв.* Бу көннән әлек булган көндә, үткән көнне. *Тышта кичә кич белән күтәрелгән буран һаман уйный иде әле.* А. Шамов. — *Кичәдән бирле күземне дә йомганым юк.* М. Гафури. || *күч.* Якын үткәндәге вакытта, күптән түгел. *Кичә булсам хат ташучы, Иртәгә мин — инженер!..* М. Җәлил.

КИЧӘ II *и.* 1. *иск. шигъ. к.* кич 1. *Аяз, матур, тын айлы кичә иде.* Г. Ибраһимов. *Үтә кайгыда кичәм һәм көндезем.* Г. Тукай.

2. Кунаклар белән үткәрелә торган кичке мәҗлес. *Шакир бүгенге кунаклар кичәсендә дсманы очратачагына ышан[ды].* Ф. Әмирхан. || Нәрсәгә дә булса багышланган кичке җәмәгать җыелышы. *Әдәбият кичәсе. Ял кичәсе. Дингә каршы кичә.* □ *Кичә чиксез матур иде. Көлү, җыр һәм уеннар.* М. Җәлил. *Унынчы класс укучылары - - - Кызыл Армия көненә багышланган кичәгә үзешчән спектакль хәзерлиләр иде.* Г. Әпсәләмов.

КИЧӘ-БҮГЕН *рәв.* Кичә һәм бүген, бер-ике көн эчендә; әле генә, яңа гына. *Ниһаять, без бәбкә мамыгыдай йомшак яшеллек белән, кичә-бүген генә ачылган чәчәкләр белән бизәлгән тауга җиттек.* Ә. Еники.

КИЧӘГЕ *с.* Кичә булган, кичә эшләнгән. *Кичәге эш.* □ *Әчтә кичәге борчылуларның тик ачы калдыклары гына бар.* Г. Ибраһимов. *Гөлсем апа - - - кичәге хатасын төзәтергә ашыкты.* Г. Гобәй. || *күч.* Үткән чордагы, әлекке замандагы. *Заман һәр көн башка заман. Казан һәр көн башка Казан, Ул кичәге Казан түгел, Үзгәрә бара һаман.* Н. Исәнбәт. *Кайберәүләр, - - - замана таләпләрен онытып, кичәге кешегә әверелә.* А. Тимергалин.

КИЧӘГЕНӘК *рәв. сөйл. к.* кичә I. *Абый җиңгине кичәгенәк күрше авылдагы бабаларына кунакка дип алып киткән иде.* М. Гали. [*Галимә апа*] *Җәй дә шат, көз дә шат, кичәгенәк тә шат иде.* М. Гафури.

КИЧӘГЕ'ЧӘ *рәв.* Кичә булганча, кичәге шикелле. [*Газиз:*] *Зәйнәп, синдә нихәл? — Кичәгечә.* Ф. Әмирхан. *Иртәнге аштан соң ротаны, нәкъ кичәгечә, өйрәнү занятиеләренә алып чыктылар.* М. Әмир.

КИЧӘЛЕ-БҮГЕНЛЕ *рәв. к.* кичә-бүген. — *Бодайның чылап торып өлгерүе кичәле-бүгенле генә бит!* Г. Гобәй. *Кичәле-бүгенле табигатьтә бөтенләй сирәк очрый торган бер күренеш: бистә бакчаларында ал-*

магачлар икенче тапкыр чәчәк ата башладылар. Г. Әпсәләмов.

КИЧӘЮ *ф. диал. к.* кичләү 1. *Вакыт инде яхшы гына кичәйде, караңгы төшеп килә.* Шура. *Көн кичәйгәч, мич төбеннән Өйгә төн чыга.* Х. Туфан.

КИЧҮ I *ф.* 1. Үтү, үтеп чыгу (гадәттә елга аркылы, шулай ук үтүе кыен булган урыннардан). — *Безнең бу походыбыз икешәр километрлы биек тауларны, ыргылып аккан тирән суларны җәяү кичүгә бәйләнгән.* Т. Гыйззәт. *Боз ачылгач, Идел кичү уңайсыз булыр.* М. Галәү. *Алар фронт сызыгын кичтеләр.* И. Гази. || *күч.* Зур каршылык, кыенлыкларны җиңеп чыгу турында. *Туган илнең тынычлыгы өчен Утлы давылларны кичәрбез.* Ә. Ерикәй. *Кыю кичтем сугыш газабын.* М. Хөсәен.

2. Үтү, узу (ара, ераклык, юл һ. б.). *Сикерә-сикерә юл кичә, куянмы икән, ак нәрсә?* Җыр. *Лизалар тора торган дачага бару өчен, татарлар күбрәк тора торган берничә урамнарны кичеп, шәһәр янындагы бер кырга чыгарга кирәк иде.* Ф. Әмирхан. || Шул ук мәгънәдә (вакыт турында). *Минем өчен көннәр әкрен кичәләр.* Г. Тукай. *Берничә куркынычлы секунд хәрәкәтсез кичте.* Ш. Камал. || *сир. иск.* Күчеп китү. *Кәрван кичәр — ут калыр, Халык кичәр — йорт калыр.* Мәкаль.

3. Кайдадыр булу; йәреп чыгу, гизү. *Бөек Уралның таулары арасында зур күлләр буена салынган заводларны, шахталарны кичтем.* Г. Ибраһимов.

4. *сир. к.* кичерү I (2 мәгъ.). *Сез килегез, якын дус итеп, Күп кайгылар кичкән анага.* М. Җәлил.

КИЧҮ II *и.* Елганың икенче ярына җәяүләп яки ат белән үтәрлек, кичәрлек сай, сөзәк ярлы урыны; елга үткеле. *Илгизәр белән берничә малай трактор-га җайланган тырмалар төркемен, күпергә сыймаганлыктан, кичүдән чыгарып яталар.* Г. Бәширов. [*Малай*] *бу тирәдәге кичүләрне, сукмакларны яхшы белә икән.* М. Шабай. || Елга аша икенче ярга чыгару өчен махсус җиһазландырылган урын. *Эшчеләр ашыга-ашыга кичү төбенә җыела башладылар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

◇ **Кичү бирү** — саегу, бер ярыннан икенче ярына кичәрлек хәлгә килү. *Агыйделнең суы кибә: әүвәле ат йөздереп йөргән җирләр кичү бирә.* М. Әмир. *Кичү бирмәс елга юк, Батыр җиңмәс дошман юк.* Мәкаль.

КИЧҮ III *ф. иск.* 1. Гафу итү, кичерү. *Булса сезнең күңелегездә дә генә шәфкать әгәр, — Кичегез!* һ. Такташ. *Кичә күр, бер сине көйдерсә аһым.* Дәрдмәнд. *Яратканга бар да кичелә.* Мәкаль.

2. Кемнән яки нәрсәдән дә булса ваз кичү, баш тарту. [*Шаһзадә:*] *Мал — фани нәрсә, --- бу малдан кичтем.* К. Насыйри. *Дөньяда булган башка матурлардан Күз йомып, барчасыннан инде кичтем.* М. Гафури.

КИЧҮЛЕК *и. к.* кичү II. *Кичүлектә дошман гаскәрләрен камап алу.*

КИШЕР *и.* Зонт чәчәклеләр семьялыгыннан кызгылт сары төстәге озынча юан азык тамыры булган бакча үсемлеге; яшелчә. *Яңгыр булмаган быелгы шикелле язда кәбестәләр генә түгел, кишер, чөгендер кебек үсемлекләр дә су даулыйлар.* Ш. Камал. || Ашамлык әйбере буларак, шул үсемлекнең тамыр өлеше. — *Суган әрчү, кишер кыру синең эшеңме?* З. Мансур. — *Әнә Сөембикә сеңелкәш үзенең яшелчә бакчасыннан алган кәбестәсеннән, кишереннән, помидорыннан һәр көз диярлек безгә өлеш чыгарып килә.* Ә. Еники. || *с. мәгъ.* Шуннан хәзерләнгән. *Кишер боткасы. Кишер бәлеше.* □ [*Юлчылар*], *бик ашыкканга күрә, чишенмичә генә икешәр стакан сөтле кишер чәе эчтеләр.* Ә. Еники.

КИШМИШ *и. сөйл.* Төшсез вак җимешле виноград сорты; шуның җимешләреннән киптереп әзерләнгән йөзем. [*Илгизәрнең*] *базарда кишмиш сатып йөргәнен күргәннәр. Туйга, гөбәдиягә дигән кишмиш иде бит.* Ә. Камал.

КИШТӘ *и.* 1. Төрле әйберләр кую өчен стенага яки шкаф эченә горизонталь итеп беркетелгән такта; шүрлек. *Габденнасыйр киштәдән курай алды да озын көйгә уйнарга кереште.* М. Гали. *Түрдәге киштәне нигытып, бар булган байлыгымны — Гоголь томнарын, конспект дәфтәрләрен тезеп куйдым.* А. Тимергалин. || Ике стена арасына буйдан-буйга беркетелгән бер яки рәттән берничә озын такта яки колга. [*Кызлар*] *юкә киштәне ике башыннан бауга элгәннәр дә киндерләрен шуңа аркылы асканнар.* Г. Бәширов. || Тимер юл вагонында яту яки әйбер кую өчен махсус урын. *Вагонның киштә такталарыннан чи нарат чәере исе килеп тора.* Ш. Усманов.

2. *күч. к.* китапханә 3. *А. Алишның әкиятләре теләсә кайсы телдә дә балалар әдәбияты киштәсен бизәрлек.* Г. Әпсәләмов. *„Онытылмас еллар" трилогиясе --- Совет әдәбияты киштәсендә дәрәҗәле урын алган җитди әсәр.* М. Әмир.

КИШТӘЛЕ *с.* Киштәләп эшләнгән. *Гөлләр өчен киштәле аслык.*

КИШТӘЛЕК *и.* Киштәгә яраклы колга, киртә. [*Әтерүш машинасына*], *тегеннән-моннан кайтышлый, юк-юк та агачын, киштәлеген салып кайта.* Ф. Хөсни.

КИШТӘЛӘП *рәв.* Катлы-катлы итеп, берничә катлы киштәләр формасында, яруслап. *Киштәләп салынган әкәмәт урын икән ул театр. Бар киштәләре дә* [*халык белән*] *шыгрым тулы.* К. Нәҗми.

КИШӘНКЕ *и. диал. к.* кәшәнкә I. *Чикләвекне, кишәнкесеннән аерып, иген шикелле келәт бураларына тутырып куялар икән.* М. Гали.

КИШӘРЛЕК *и.* Эшкәртү (сөрү, чәчү, утау, уру һ. б.) өчен бүлеп алынган тар, озын җир мәйданчыгы; ал, алым, буй. *Уракчылар, кул асларына алган кишәрлекләрен биш-алты таяк буе урып, берничәшәр өем куй[дылар].* М. Гали. *Басуда Сабираның кишәрлеге җир уртасына, урманнан ерак урынга туры килгән икән.* Ә. Фәйзи. *Аланның печәнен чаптырмыйлар. Уткән-суткән юлаучылар гына анда бер кишәрлек, монда бер уйдык чабып арба төпләренә салып киткәлиләр.* А. Гыйләҗев.

КИШӘРЛЕКЛЕ *с.* Кишәрлекләргә бүленгән.

КИШӘРЛЕКЛЕ-КЕШТӘКЛЕ *с.* Төрле формадагы кишәрлекләргә бүлгәләнеп беткән. *Кайда иңе ун чабата буе, кайда биш-алты саженьлы кишәрлекле-кештәкле, ыштан балагыдай тар җирләр хәзер, йөзәр, меңәр гектары бергә кушылгач, --- матурланып киткәннәр.* Г. Бәширов.

КИШӘРЛЕКЛӘП *рәв.* Җир мәйданчыгын кишәрлек-кишәрлек итеп бүлеп. [*Чәчүдә*] *эшне кишәрлекләп-кишәрлекләп бүленеп эшләделәр.* Ф. Хөсни.

КИЮ *ф.* 1. Гәүдәнең бер өлешен нинди дә булса кием белән каплау. *Аякка кию. Бияләй кию.* □ *Сабир абзый җәһәт кенә чөйдән кара тунын алып кия башлады.* Ә. Еники. *Зәңгәр яулык, кызыл күлмәк, Кызлар кия көз булгач.* Җыр.

2. Берәр әйберне үзеңә җайлап беркетү, тагу. *Коньки кию. Күзлек кию.* □ [*Юлчылар*] *әкренләп сумкаларын кия башладылар.* Ш. Камал.

3. *күч.* Нәрсә белән дә булса каплану (гадәттә яшеллек, яфрак белән — үсемлекләр, җир турында). *Йомшак нурлар сибә-сибә килә май, Яшел киемнәрен кия киң тугай.* Ә. Ерикәй.

КИЯ *с. иск.* Зарар. *Авыруның иясе була, дарудың кыясе була, ди.* Мәкаль.

КИЯЛЕК *и. иск.* Зарар, афәт. [*Күрәзәче — Янгурага:*] *Бөтен кыпчак, Болгар йортына киялек китердең.* Н. Исәнбәт. *Әллә теге чакта - - - борын чөергән булуның киялеге килде микән?* Ш. Маннур.

КИЯҮ *и.* **1.** Тормыш иптәше (хатын-кызга карата), ир. [*Шәмсинур:*] *Алай көндәш өстенә чыкмасак та кияүсез калмабыз әле.* М. Гали. — *Каян гына табарга икән шушы Зәйнәпбануга бер кияү?* Г. Бәширов. — *Кызым — инженер. Кияве белән Омскида торалар.* Р. Ишморат.

2. Яңа өйләнгән егет яки ир кеше; кәләшнең булачак ире (туй вакытында һәм кияүләп йөрү чорында). [*Кунаклар*] *кияү белән кызны котлый-котлый - - - кулларындагы бокалларын бушаттылар.* А. Шамов. [*Нигъмәт кунакларга:*] *Ягез, әйдә, утырышыгыз. - - - Тиздән кияү белән кыз да кайтып җитәрләр инде.* Г. Камал.

3. *этн.* Кызының яки үзеннән яшьрәк кыз кардәшенең ире (ата-ана һәм өлкән туган-кардәшләр ана шулай дип эндәшәләр). — *Әткәй, без әле киявегез белән сезгә бер эш белән килгән идек.* Ф. Әмирхан. — *Монысы, хажи әфәнде, үзебезнең кияү тиешле кеше, өлкән сеңелебезнең хәләл җефете.* Ш. Камал.

Кияү бүлмәсе *этн.* — кыз йортында кияү белән кызны үзләрен генә калдыру өчен махсус җиһазландырылган бүлмә. [*Хатын-кызлар*] *ашыгыч рәвештә кияү бүлмәсен зиннәтлә[деләр].* Г. Ибраһимов. **Кияү бүләге** *этн.* — кияүнең булачак хатынына һәм аның ата-анасына, туганнарына биргән бүләкләре (кием-салым һ. б. әйберләр). **Кияү егете** *этн.* — туй вакытында кияү йомышларын башкаручы (аның иң якын дусларыннан берсе). *Газинурның кияү егете һәм табынны алып баручы Һашим, әледән-әле Сәлим янына килеп, аның колагына нидер пышылдады.* Г. Әпсәләмов. **Кияү егете кебек** *шаяр.* — купшы, матур киенгән ир кеше турында. **Кияү камчысы** *бот.* — *к.* тәмлекәй. *Юл читендә зәңгәр тубал булып кияү камчылары, зәңгәр күзләр, аклы-сарылы яулык бөркәнгән ромашкалар кала.* А. Гыйләҗев. **Кияү керү, кияү булып керү** *этн.* — егетнең, кияү (1 мәгъ.) булып, беренче мәртәбә кыз янына ялгыз керүе. *Нури карт, җиңелчә бер көлү белән көлеп, - - - кияү булып кергән көннәрендәге рәхәтлекләрен сөйли.* М. Гафури. **Кияү кертү** *этн.* — хатын-кызның (гадәттә тол хатынның) кияү (1 мәгъ.) булачак кешесен үз йортына кабул итүе; йортка кертү. — *Менә күрерсез: Нуретдинның „кырык кичәсе“ үтәр-үтмәс Мәдинә йортка кияү кертәчәк.* Ш. Камал. **Кияү пилмәне** *этн.* — итенә йомырка сытып, бик юка камырлы һәм бик вак итеп пешерелгән пилмән. **Кияү пәрәмәче** *этн.* — йомырка сытып, сөткә генә изелгән эче камырдан пешерелгән пәрәмәч. **Кияү өстәле** *этн.* — кияүне сыйлау өчен хәзерләнгән өстәл. [*Җәлә л:*] *Монда кияү өстәле хәзерләячәкләр.* Ш. Камал. **Кияүгә бару (китү, чыгу)** — кемнең дә булса хатыны булу. — *Кияүгә барырга ашыкмыйм, миңа кызлык гомере кызыклы.* Г. Тукай. *Усман дигән егет Гөлйөземне бик яшьли сихерләде, ике ел йөргәч, шуңа кияүгә дә чыгып куйды.* Г. Ибраһимов. **Кияүгә бирү** — халыктагы йола буенча, кызны, егет белән кавыштырып, ирле итү. — *Менә синең үзеңне дә шундый кызыл туйлар ясап кияүгә бирербез әле.* Г. Камал. **Кияүдән кайту** — ирдән аерылу. [*Дгъзәметдиннең*] *кияүдән кайткан бер кызы бар.* А. Шамов.

КИЯҮЛЕК *с.* Кияү булу хәле. — *Малайга кызыбызны бирергә күнгән булып, тик, безгә кияүлеккә лаек булу - - - өчен дип, Казанга барып ике ел укып кайтуын шарт иттек.* М. Фәйзи.

КИЯҮЛӘҮ *ф. этн.* Кияүнең кыз йортында кунак булып ятуы турында. [*Садыйк:*] *Туй итеп ике көн кияүләгәч, Нәгыймә белән калага китәбез.* Г. Ибраһимов. *Син җаныйны алыр булсам, өч ел йөрер идем кияүләп.* Җыр.

КИҖЕ *и.* Машина ысулы белән фабрикада эрләнгән нечкә мамык җеп. || Кызыл төстәге шундый җеп. *Киҗе кушып сугылган сөлге.* □ [*Староста*] *өч күк, бер киҗе атып суккан иске киндер букчасыннан приказ белән газеталарны сөйрәп чыгарды.* Х. Кәрим.

КИҖЕЛЕ *с.* Киҗе катнаштырып сугылган тукымадан тегелгән. *Киҗеле күлмәк. Киҗеле чаршау.* □ *Киҗеле ашъяулык җәйгән өстәлдә, бизәкле поднос өстендә, самовар шаулый.* Г. Әпсәләмов.

КИҖЕЛӘП *рәв.* Киҗе аралаштырып. *Хәрниса - - - киҗеләп суккан альяпкыч белән француз яулыгын юып алдан әзерләп куярга дип күңеленә беркетте.* Ф. Хөсни.

КИҖЕ-МАМЫК *с.* **1.** Мамык җептән эшләнгән. *Киҗе-мамык тукыма.* || *и. мәгъ.* Шундый җептән эшләнгән тукыма. *Нурый карт - - - төпчек кызының тегү-чигүләре, киндерләре өчен кирәк җепне, җитенне, киҗе-мамыкны, буяуны, дебетне алып бирә торды.* Г. Ибраһимов.

2. Мамык эшкәртүгә, мамыктан җеп, тукыма җитештерүгә бәйләнеше булган. *Киҗе-мамык промышленносте.*

КИҢ *с.* **1.** Аркылысы, иңе озын, зур булган; *киресе:* тар. *Киң урам. Киң ишек. Киң җилкәле. Киң экранлы фильм.* □ *Киң Иделнең ярларына Сыеша алмый ага боз.* М. Җәлил. *Киң тротуар тулы җәяүле кайный.* Г. Галиев. *Әнә сузылып ята киң юллар, Матур шәһәрләр, ямьле авыллар.* З. Мансур.

2. Зур мәйдан (урын, аралык) алып торган, тирәякка бик ерак сузылган; иркен. *Киң кырлар. Киң дала.* □ *Менә шундый киң безнең ил, Менә шундый зур безнең җир!* Ә. Исхак. *Ындыр табагы кебек тап-такыр киң мәйдан бушап калды.* Ф. Бурнаш. *Төн тыныч. Киң күк йөзендә ай гына тик нурлана.* Н. Исәнбәт. || Аркылысы, иңе зур, иркен булган, тәнгә ятып тормый торган (кием-салым турында). *Киң чалбар. Киң итәкле күлмәк.* □ *Атлы казак - - - каршыга сибеп яуган яңгырдан битен киң җиңе белән ышыклады да Бикмуш бабай белән Илсөяр артыннан китеп барды.* Г. Гобәй.

3. *күч.* Аяк яки кул хәрәкәтләреңең эре һәм салмак булуы белән аерылып торган. *Киң адымлы йөреш. Киң колач белән йөзү.* || Иркен, сузынкы. [*Газинур*] *гына бу җырны шулай киң сулыш белән, бар дөньяга ишеттерергә теләгәндәй кычкырып җырлый.* Г. Әпсәләмов. *Әллә кайдагы бер фабрика моңлы гына, киң генә тавыш белән озак сузып сызгыртты.* Ф. Әмирхан.

4. *күч.* Күләме белән зур, күп нәрсәләрне эченә алган. *Киң полотнолы әсәр. Киң проблема кую.* □ *„Козгыннар оясында“ — киң социаль тормышны гәүдәләндергән тарихи сюжеттагы пьеса.* Г. Нигъмәти.

5. *күч.* Тулы, бернәрсә белән дә чикләнмәгән. *Киң мөмкинлекләр.* □ [*Нәсимә:*] *Бәхет ишеге киң күләме белән ачыла.* Ш. Камал. *Октябрь революциясенә кадәр музыка татар культурасы үсешендә киң хокук белән файдалана алмады.* М. Җәлил. || Тулы, күпьяклы, тирән. *Киң белемле кеше.* □ [*Г. Камал*] *иҗаты турында төплерәк һәм киңрәк тикшеренүләр Г. Кашшаф, Х. Хәйри һәм Г. Халит иптәшләр тарафыннан ясалды.* М. Гали. || Иркен, ирекле. *Һөнәрлегә мәйдан киң.* Н. Исәнбәт. *Дөнья якты һәм киң.* Г. Ибраһимов.

6. *күч.* Зур күпчелекне, күпләрне эченә алган; барлык. *Киң хезмәт иясе халкы. Киң катлау укучылар. Киң массага җиңел аңлашылырлык телдә*

язу. || Бөтен кеше өчен, күпчелек өчен билгеләнгән. *Киң кулланыш товарлары.* || *рәв. мәгъ.* Күпчелеккә барып житәрлек, күпләрне җәлеп итәрлек итеп, зур масштабта. *Социалистик ярышны киң җәелдерү.* □ *„Ләкин, дисең, исеме [Фәсхинең] киң таралган...“ Көнләшәсең, ахры. Булыр да.* З. Мансур.

7. *рәв. мәгъ. күч.* Күп, еш. *Тукай --- татар фольклор байлыгыннан шигъри иҗатында киң файдаланды.* Г. Нигъмәти. *Революция башларында [Г. Камал], сатирик шигырьләр жанрын киң кулланып, политик-актуаль темаларга күп кенә шигырьләр яза башлады.* М. Гали.

Киң итеп — 1) тулысынча, бөтен киңлегенә. *Вагон ишеген киң итеп ачып җибәрдем.* Ш. Усманов; 2) тулы, җентекләп (сөйләү, таныштыру, язу һ. б.). *[Нәгыйм] үзенең бу турыда Сәләхи һәм Мостафа белән тарткалашуын киң итеп сөйләде.* Ш. Камал. **Киң әйтелешле** *лингв.* — авыз куышлыгын зур ачып әйтелә торган. *Киң әйтелешле авазлар* (мәсәлән, рус теле аша кергән сүзләрдәге о, э, ы авазлары).

◇ **Киң колач алу (җәю)** — киң таралу, зур күпчелекне җәлеп итү. *Петроград эшчеләренең чыгышлары киң колач ала башлады.* К. Нәҗми. *Котельниковларның башлангычы заводта көннән-көн киңрәк колач җәя иде.* Г. Әпсәләмов. **Киң колачлы** — 1) төрле өлкәдә нәтиҗәле эш күрсәтә торган, төрле өлкәдән хәбәрдар булган. *Киң колачлы галим.* □ *[Мостафа:] Иванов — киң колачлы, эшлекле, уңган егет.* Г. Кутуй; 2) күп нәрсәләрне эченә алган, төрле тармакка (өлкәгә) караган, күпьяклы. *Тәнкыйть киң колачлы, зур эрудицияле --- булырга тиеш.* Г. Гали. **Киң колачлылык** — киң колачлы булу. *Романга киң колачлылык, масштаблык хас булу.* **Киң күнелле** — кешелекле, ярдәмчел; кунакчыл. *Нинди саф һәм киң күнелле Илемнең халкы.* Ф. Кәрим. **Киң фронт буенча (белән)** — төрле өлкәләрдә, күпьяклы. *Г. Ибраһимов --- киң фронт буенча хезмәт алып бара торган универсаль кеше.* Г. Гали. *[Илдә] социалистик җәмгыять төзү эше киң фронт белән җәелеп китте.* Х. Госман.

КИҢЕ'НЧӘ *рәв. сир.* Бөтен киңлегенә, тулысынча; киң итеп. *Шәһәр думасының ишекләре киңенчә ачык, кешеләр кырмыска шикелле кайнаша.* Ш. Камал. *Сыерлар абзарының урта ишеге киңенчә ачык.* Ә. Еники.

КИҢЛЕК *и.* **1.** Киң булу хәле, сыйфаты. *Иңбаш әгъзаларының киңлеге, кулбаш әгъзаларының [әрелеге [Шәрәфи картны] шактый дәү күрсәтә иделәр.* Ш. Камал. *Этаж саннары белән җиде-сигезгә үрләп, киңлек, зурлык исәбе белән бөтен кварталлар өстен каплаган бу магазиннар чынлап та башны әйләндерәләр.* Г. Гали.

2. Нәрсәнең дә булса аркылы озынлыгы, ине. *Күкнең киңлеге — кояш йөреше белән бер көнлек юл.* Әйтем. *[Разведчиклар] өч-дүрт метр киңлегендәге елга янына килеп чыктылар.* А. Шамов. *Ишек пычак йөзе киңлеге генә ачылды.* Г. Гобәй.

3. Ачык, иркен, гаять киң мәйдан. *Океан киңлекләре.* □ *Чал Урал тауларын кисеп, Себер киңлекләренә чыктык.* Ш. Маннур. *Җаекның Бохара ягы дип аталган аргы ягы гаять тын киңлек булып җәелеп ята.* Ә. Фәйзи. || Төрле юнәлештәге чиксез аралык, бушлык; пространство. *Космик киңлекләрне үзләштерү.* □ *Кыю һәм горур Җәп кочагын, Зәңгәр киңлектә Оча яшь лачын.* З. Мансур.

4. *геогр.* Экватордан меридиан буенча (көньякка яки төньякка таба) градуслар белән күрсәтелгән ара. *Челюскинчылар үзләре төшкән бозның 68° төньяк киңлектә һәм 173° көнбатыш озынлыкта булуын радио аша хәбәр иттеләр.* СССР физ. геогр. || Экватордан **теге** яки **бу** ераклыкта яисә юнәлештә булган урын. *Көньяк киңлекләрдә һава торышының кинәт үзгәрүе.*

5. *күч.* Күпьяклылык, тулылык, тирәнлек (иҗади эштә). *Эшче театрының составына килгәндә, анда күпчелеге бик аз стажлы яшь кенә көчләрнең туплануына карамастан, иҗат мөмкинлекләренең бик киңлеген әйтергә кирәк.* М. Җәлил. *Колач җәйсәң — колач җитми аңа, Күз юнәлтсәң — чиге юк аның. — Шундый киңлек Пушкин, шундый дөнья, Гүзәллектә тиңе юк аның.* Ш. Маннур.

6. *күч.* Иркенлек. *Күңелләр, иксез-чиксез киңлекне тоеп, каядыр ашкыналар.* Г. Әпсәләмов. *Монда киңлек, монда җәннәт, Ни кирәкләр бар да бар.* Г. Камал.

КИҢЛӘП *рәв. сир.* Киң итеп, озын һәм җентекләп, бәйнә-бәйнә. *Гайшә Паларусовка [гаиләнең бөтен тарихын] болай киңләп сөйләмәде.* Г. Ибраһимов. *Автор безне --- Баязит карыйның бала, шәкерт вакытында күргәннәре белән киңләп таныштыра.* Г. Нигъмәти.

КИҢСУ *с. Кимл. дәр. к.* киң (1, 2 мәгъ.).

КИҢЧЕЛЕК *и. сир.* Иркенлек, хөрлек; бар як җитеш булу хәле. *Киңчелек булмый[ча], тиңчелек булмый.* Мәкаль. *Ул вакытта --- бик киңчелек, бик муллык булган.* М. Гали.

КИҢЧӘ *с.* Киң генә, киңсу. *Киңчә йөзле, кысыграк күзле --- бер чибәрне Нарспи [дип таныштырдылар].* Г. Бәширов. *[Яков] буйга кечерәк, киңчә гәүдәле --- егет иде.* М. Әмир.

КИҢӘЙТЕЛҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* киңәйтү.

2. *с. мәгъ.* **киңәйтелгән.** Составы, күләме, эчтәлеге белән гадәттәгедән тулырак. *Киңәйтелгән программа. Киңәйтелгән җитештерү. Гыйльми Советның киңәйтелгән утырышы.* □ *Тиздән газетабызның киңәйтелгән номеры чыга.* К. Нәҗми.

КИҢӘЙТҮ *ф.* **1.** Киңрәк итү. *Юлны киңәйтү. Урынны киңәйтү.* □ *Киңәйтегез мәйдан түгәрәген, Көрәшчеләр чыксын уртага.* Ә. Ерикәй.

2. Арттыру (санын, күләмен, мөмкинлеген). *Чәчү мәйданнарын киңәйтү.* □ *Татар театры төзелеп, эшли башлагач ук, Г. Камал [әүвәлге] әсәрләрен сәхнәгә куярлык итеп яңадан киңәйтеп яза.* М. Гали. *— Син, кредитка эш итүдән куркып, егерме биш еллык сәүдәңдә эшеңне 25 процентка да киңәйтә алмагансың.* Ф. Әмирхан. || *рәв. мәгъ.* **киңәйтеп.** Тулы итеп, җентекләп яки булмаганны арттырып, өстәп (сөйләү турында). *Усал телләр моны [гайбәтне] тагы киңәйтеп, кабартып сөйли башладылар.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Баету, тирәнәйтә төшү, үстерү (аңны, карашны, белемне). *Бу еллар Такташның тормышка караш горизонтын киңәйтә төштеләр.* Г. Нигъмәти. *— Акылны селкеп-кагып эшләтергә, аңны киңәйтергә кирәк.* Ш. Камал.

КИҢӘШ *и.* **1.** Ничек эшләргә кирәклек турында үгет-нәсихәт, күрсәтмә, тәкъдим. *Киңәш бирү. Киңәш сорау. Файдалы киңәш.* □ *Айсылу үзеннән күп яшь булса да, Тимери аның киңәшләреп --- чын күңелдән тыңлый иде.* Г. Бәширов. *Киңәшем шул: җирдә иң кадерле Бу дуслыкны, бәгърем, югалтма!* М. Җәлил.

2. Киңәшмә, фикер алышу. — *Сораулар бетте, суд киңәшкә керә, ярты сәгатьтән хөкем карары игълан ителер.* М. Гали. *Без барабыз үзәккә, Җитәкчеләр янына Кремльгә киңәшкә.* Ф. Бурнаш.

3. Киңәшләшеп хәл итә торган мәсьәлә, эш. — *Якуб абый, синең белән бер киңәш бар әле.* И. Гази. *— Ә мин сиңа зур гына киңәш белән килдем.* Ш. Камал.

Киңәш итү — 1) киңәш (1 *мәгъ.*) бирү; тәкъдим итү, ни эшләргә кирәклеген әйтү. *Докторлар миңа, берничә айга авылга китеп, табигать эчендә яшәргә киңәш иттеләр.* А. Шамов; 2) киңәш сорау, фикер алышу; киңәшләшү. *Кешегә киңәш ит, үзеңнекен эшлә.* Мәкаль. — *Тукта, анасы, синең белән һич юньләп киңәш итеп сөйләшер хәл юк — елый башлыйсың.* Ф. Әмирхан.

◇ **Киңәш бирегү** — үзара аңлашу, килешү. — *Патшаларның киңәше берексен иде дә, [тизрәк сугыш туктасын иде].* М. Гали. **Киңәш бирү тавышы** *полит.*— тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен әйтә алу, ләкин бу мәсьәләләрне тавышка кую юлы белән хәл итүдә катнаша алмау хокукы. — *Тавыш бирүгә комсомол членнары катнашмыйлар, алар киңәш бирү тавышы белән генә катнашалар.* Ш. Камал. **Киңәш кору** — *к.* киңәшләшү. *Юл буенча Мәрхәбә белән Шәйхел киңәш корып килделәр.* Г. Ибраһимов. **Киңәш тоту** — кемнең дә булса киңәшен тыңлау, шул киңәш буенча эш итү. *Бу вакытта яралы хатын, доктор киңәшен тотып, кыл кыймылдатмыйча ята иде.* Г. Гобәй. **Киңәшкә килү** — 1) үзенең киңәше, акыллы сүзе белән ярдәм итү; 2) кеше киңәшен тыңлау. — *Картлар киңәшкә килүчән була ул, Гөлсем сеңелем, хак сүз!* Ф. Бурнаш; 3) үзара аңлашу, килешү. [*Малайлар*], *ниндидер бер киңәшкә килеп, өерләре белән басу капкасына йөгерделәр.* И. Гази. **Киңәштән чыкмау** — кеше киңәшен тоту, бирелгән киңәш буенча гына эш итү.— *Әйтегез үзенә [Батырҗанга]: минем киңәшемнән чыкмасын.* Ф. Бурнаш.

КИҢӘШЕ'НЧӘ *рәв.* Кемнең дә булса киңәше буенча; киңәш иткәнчә. *Искәндәр, әтисе киңәшенчә, кармак җебен кулына урап, басмадан ярга сикерде.* Г. Минский.

КИҢӘШЛЕ *с.* Киңәшеп эшләнгән. *Киңәшле туй тараллмас, дигәннәр картлар.* А. Шамов. *Киңәшле эш уң булыр.* Мәкаль.

КИҢӘШЛӘШҮ *ф.* Нәрсәне дә булса бергәләп тикшереп карау, уйлашу, фикер алышу.— *Минем карчык нәрсәдер уйлый әле, — диде дхмәт, — булмаса, иртәгә хәтле срок бирегез, без аның белән киңәшләшербез.* Ш. Камал. *Фәйрүзәнең, көн дә Җыеп бригаданы, Нидер киңәшләшүе Юкка булып чыкмады.* М. Җәлил.

КИҢӘШМӘ *и.* Аерым бер мәсьәлә буенча киңәшләшү, фикер алышу максаты белән үткәрелә торган җыелыш, утырыш. *Авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсе.* □ [*Газинур*], *леспромхозның иң яхшы эшчеләреннән берсе булып, [шәһәргә] киңәшмәгә бара.* Г. Әпсәләмов. *Бүген культура йортында алдынгы терлекчеләр киңәшмәсе ачылды.* Г. Мөхәммәтшин.

КИҢӘШ-ТАБЫШ *җый. и.* Төрле киңәшләр. *Карчыклар арасыннан киңәш-табыш бирүчеләр дә булды.* Г. Бәширов. — *Арада киңәш-табышка ярарлык бер укыганрак, башлырак кеше булсын иде.* М. Гали.

Киңәш-табыш итү (кору) — киңәш сорау, киңәшләшү. — *Мин, Гомәр абзый, бу турыда эти белән киңәш-табыш итеп карыйм әле.* Ф. Әмирхан. *Гафиятулланың улы белән - - - иркенләп бер киңәш-табыш корып утырасы килгән иде.* Ф. Хөсни.

КИҢӘШ-ТАБЫШЛАШУ *ф.* Киңәшләшү, киңәш-табыш итү. — *Менә шулай, соңынтын сүз булмасын өчен алдан киңәш-табышлашып кую яхшырак.* С. Рафиков.

КИҢӘШТӘШ *и.* Киңәшләшә торган якын кешө. *Яннарында утырырмын, Киңәштәшең булырмын.* Э. Ерикәй.

КИҢӘШ-УҢАШ *җый. и. к.* киңәш-табыш. *Озак киңәш-уңаш иткәннән соң, шундый карарга килгәннәр.* Н. Исәнбәт.

КИҢӘШЧЕ *и.* Киңәш бирүче. *Зур гакыллы яхшы киңәшчебез Арабызда бүген юк инде.* Ш. Маннур. *Иң якын киңәшчене Эзләмә әллә каян, Үз акылыңа ышан да Үз йөрәгеңә таян.* Ш. Галиев.

КИҢӘШЧӘН *с.* Киңәшеп эшләүчән. *Таләпчән кеше ул. Шул ук вакытта киңәшчән дә.* Соц. Тат.

КИҢӘШҮ *ф. к.* киңәшләшү. *Бу турыда уйлаганда ул ихтыярсыз кешеләр белән киңәшү, аларның ярдәме кирәклеген сизә иде.* Ә. Еники. *Алар, сәкедә яткан Иргалинең янына утырып, төрле сораулар бирделәр һәм үзара нидер киңәштеләр.* Ә. Фәйзи.

КИҢӘЮ *ф.* 1. Киң булу, тагын да киңрәк хәлгә килү, җәелү. *Елга киңәю.* □ *Офык буйлап сузылган таң аклыгы күзгә сизелерлек тизлек белән киңәя бара иде.* М. Әмир. *Аның болай да тулы йөзе тагын да киңәеп, тулыланып китте.* А. Әхмәт.

2. Сан, күләм, көч-куәт ягыннан арту, эреләнү, зураю. *Тышкы базар киңәю. Эшчәнлек киңәю.* || Тулылану, күпьяклырак булу. *Октябрьдан соң Г. Камал - - - иҗатының тематикасы һәм әхтәлеге дә киңәйде.* М. Гали. || Киңрәк таралу, киң массаны җәлеп итү, көчәю. — *Революция үсәр, киңәер,* — *ул вакыт җир дә булыр, власть та булыр.* И. Гази. *Ул мөкатдәс теләк безнең — Яңадан алга бару, Яшәрү, үсү, киңәю, Яңарту һәм яңару.* Ә. Ерикәй. *Кыр эшләре башлануга, [ярыш] тирәнәйде, киңәеп китте.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Баю, тирәнәю, үсү (ан, белем, караш турында). — *Аралашу файдасыз түгел ул, Мәдинә. Төрле сүз, төрле фикер ишетәсең, күңел ачыла, дөньяга караш киңәя.* Ш. Камал.

4. *күч.* Иркенәю, иркенәйгән кебек тоелу. [*Сестра чәчәкләрне*], *лазаретка алып кайтып, сулы банкаларга утырта. Палата матурланып, киңәеп китә.* А. Шамов. *Нуры белән балкып, кояш та күтәрелде... Җаннар киңәеп үк киттеләр.* Г. Ибраһимов.

5. *рәв. мәгъ. күч.* **киңәеп.** Иркен рәвештә. *Пролетариат революциясе хезмәт иясе халык массасының киң талантларына, иҗат көчләренә, осталарына киңәеп үсәргә юл ачты.* М. Җәлил. || Иркенләп, ашыкмыйча, җайлап кына, ваклыкларына кадәр тикталып. *Ничектер, киңәеп сөйләргә җай килмәде.* Г. Ибраһимов. [*Рәхим*] *хуҗаларча бик иркенләп, киңәеп сөйләшә.* А. Расих. || Киң рәвештә, күпчелеккә барып җитәрлек булып. *Әгәр ул хәбәр киңәеп таралса, нәрсә булыр?* Ш. Камал.

КИҢӘЮЧӘНЛЕК *и. физ.* Киңәергә сәләтлелек. *Сыеклыкларның киңәючәнлеге. Газның киңәючәнлеге.*

КЛАВЕСИН *и.* Тышкы күренеше белән фортепьянога охшаган кыллы, клавишлы иске музыка коралы. [*Бүлмәдә*], *шкафлардан читтәрәк, заманасына күрә яңа клавесин тора.* Ж. Тәрҗеманов.

КЛАВИАТУ'РА *и.* Клавишлы музыка коралларында һәм кайбер механизмнарда (мәсәлән, язу машинкасында) клавишлар җыелмасы. *Аккордеон клавиатурасы. Язу машинкасы клавиатурасы. Пианино клавиатурасы.*

КЛАВИКОРД *и. муз.* Конструкциясе белән клавесинга охшашлырак иске кыллы-клавишлы бәрмә музыка коралы.

КЛАВИР *и. муз.* 1. Барлык кыллы-клавишлы уен коралларының (клавикорд, рояль, пианино һ. б.) гомуми атамасы.

2. Опера яки симфоник партитураның фортепьяно кушмалык итүендә җырлау яки фортепьянода уйнау өчен эшкәртелгән күчермәсе. *Бервакыт Муса Дминәдән „Севиль чәчтарашы" исемле операның клавирын күчереп бирүне сорый.* Х. Садрый.

КЛА'ВИШ *и.* Музыка коралы, язу машинкасы, телефон аппараты кебек механизмнарда көянтәне хәрәкәткә китерү өчен бармаклар белән баса торган төймәләр, пластинкалар. *Сафуан абзый баянны тыныч*

кына үз кулына алды да, --- көй эзләп, клавишларга баскалап алды. Ә. Баян. *Мөнирә рояль янына килде һәм --- клавишлардан озын бармакларын йөгертеп үтте.* Г. Әпсәләмов.

КЛА'ВИШЛЫ *с.* Клавишлар ярдәмендә уйнала, эшләтелә торган. *Клавишлы музыка кораллары.* □ *Арслан клавишлы телефонның бер клавишына басты.* Г. Ахунов.

КЛАДОВОЙ *и. сөйл.* Ашамлык әйберләре, шулай ук товар, чимал һ. б. ш. саклау өчен билгеләнгән бина, амбар, бүлмә. *Таш кладовой.* □ [*Сиражетдин:*] *Йөзе каралар, кладовой ишеген ачык калдырганнар.* Г. Камал. *Бүген төнлә Низам байның кладовоеннан егерме йөк кызыл мал төяп алып киткәннәр.* К. Тинчурин.

КЛАДОВОЙЧЫ *и.* Кладовой, склад эшчесе; амбарчы. *Колхоз хисапчысы белән кладовойчының исәп-хисап дәфтәрләре, сельпо кассасы, ашлык амбарлары... — һәммәсе дә аңа [Айсылуга] күчте.* Г. Бәширов.

КЛА'КСОН *и. махс.* Автомобильдә, трактордә механик сигнал гудогы.

КЛА'ПАН *и.* 1. *тех.* Нинди дә булса механизмда газ, пар, сыеклык юлын каплап тора торган махсус япкыч, каплавыч. [*Насостагы*] *дүрт чуен клапанның берсе яртылаш сынып төшкән.* Ш. Камал.

2. Тынлы музыка коралы корпусындагы тишекне ябып, ачып тора торган капкач. || Тын өреп чыгара торган тишекне каплап торучы планка, шулай ук гармонь, орган кебек уен коралларында клавиш төймәсе.

3. *анат.* Йөрәктә канның кире йөрешенә тоткарлык ясый торган япма. *Йөрәк клапаннары.*

КЛА'ПАНЛЫ *с. тех.* Клапаны булган, клапан ярдәмендә эшли торган. *Клапанлы музыка коралы. Клапанлы бүлгеч.*

КЛАРНЕТ *и.* Агачтан бер башы киңәйтеп эшләнгән курай сыман тынлы музыка коралы. *Оркестрда әле бер, әле икенче тема өскә чыкты. --- Скрипкалар үз темаларын яңадан күтәреп чыктылар. Флейта һәм кларнетларга яңадан җан керде.* Ш. Хөсәенов.

КЛАРНЕТЧЫ *и.* Кларнетта уйнаучы.

КЛАСС *и.* 1. Бүлек, төркем; катлам. *Монда халык бер-беренә каршы ике класска нык аерылышып җиткән.* Г. Ибраһимов. || *лог.* Нинди дә булса билгеле бер уртак сыйфатка, үзлеккә, мөнәсәбәткә ия булган төрдәш предметлар җыелмасы. || *биол.* Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы бүленешендә иң зур төркемнәрнең берсе. *Имезучеләр классы.* □ *К. Линней үсемлек һәм хайваннарның барлык төрләрен эре төркемнәргә — кластарга бүлгән.* Биология. || *мат.* Өч янәшә разрядлы санның цифрлар җыелмасы (мәсәлән, икенче класска берәмлек меңнәр, дистә меңнәр, йөз меңнәр керә). || Төзелеш һәм җиһазлануына карап, судно һәм корабльләрнең төре. *Миноносецлар классы.* || Поезд вагоннарының һәм пароход каюталарының пассажирлар өчен уңайлылык дәрәҗәсенә карап билгеләнгән төре. *Аларның тышкы кыяфәте беренче класс пассажирлары арасында ким-хур булырлык түгел иде.* А. Расих. [*Палубада*] *беренче һәм икенче класска билет алган кешеләр баралар.* Һ. Такташ. || Футбол, баскетбол, хоккей кебек спорт уеннарында командаларның хәзерлек һәм уен дәрәҗәләренә карап бүленгән группасы. *„Рубин“ футбол командасының „А“ классына күчүе.*

2. Бер үк уку елындагы яки (мәсәлән, художество мәктәпләрендә) махсус предмет өйрәнүче укучылар төркеме. *Скрипка классы. Унынчы класс укучылары.* □ *Бишенче класска күчкәч, без күрше авылга йөреп укый башладык.* Х. Сарьян. *Җырчылар музыка һәм вокаль буенча махсус дәресләрне аерым педагогларның классларында үттеләр.* М. Җәлил. || Бер бүлмәдә (класста) укучы балалар төркеме. *Мине VI Б классына җитәкче итеп билгеләделәр. Класс шактый зур, утыз бала.* А. Тимергалин. || Мәктәптә дәрес укытыла торган бүлмә. *Звонок, озын коридорны яңгыратып, укучыларны класска өндәде.* А. Әхмәт.

3. Нәрсәне дә булса үз ишләреннән аера, аның урынын билгели торган сыйфат, дәрәҗә үлчәве. *Беренче класс сугыш техникасы. Югары класс спорт уены.* □ *Бу машиналарның детальләре икенче класс төгәллек белән эшкәртелә.* Г. Әпсәләмов. || Хәзерлек, квалификация дәрәҗәсе. [*Зөфәр дә*] *Таһирҗан кебек икенче класс шофер икән.* Р. Шәрифуллин.

4. Җиргә шакмакларга бүленгән фигура сызып, таш яки берәр кыйпылчыкны, бер аякта сикереп, аяк очы белән бер шакмактан икенчесенә күчерүдән гыйбарәт балалар уены. *Класс уйнау.*

КЛА'ССИК I *и.* 1. Үрнәк булырлык, атаклы, киң танылган язучы, фән яки сәнгать эшлеклесе. *Марксизм-ленинизм классиклары.* □ *Классиклар әше алдында хәйран калып дөньяңны онытасың.* Г. Бәширов. *Рус һәм Көнбатыш Европа классикларының лирик иҗатлары белән таныштыруда Тукаевның ролә зур булды.* Г. Нигъмәти.

2. Сәнгатьтә классицизм тарафдары.

3. Борынгы грек, латин телләре, әдәбияты яки сәнгате белгече.

КЛА'ССИК II *с.* 1. Классиклар I (1 мәгъ.) тарафыннан иҗат ителгән, камил, үрнәк булырлык. *Классик музыка.* □ *Шагыйрь [Һ. Такташ] классик әдәбияттан традиция алу даирәсен киңәйтә бара.* Х. Госман. *Студия классик операларның тулы пәрдәләре, аерым өзекләре өстендә эшләүне планга керте.* М. Җәлил. || Иң күренекле, иң яхшы; үрнәк булырлык, атаклы. *Классик шагыйрь.* □ [*„Беренче театр“*]*—татар сәхнәсенең классик әсәре булып кала торган комедия.* М. Гали. || *күч.* Типик, бик характерлы. *Классик мисал.*

2. Классицизмга (1 мәгъ.) нигезләнгән. *Классик сынлы сәнгать.*

3. Борынгы грек һәм римлылар дөньясына караган; антик. *Классик телләр.* || Борынгы грек, латин телләрен һәм антик әдәбиятны өйрәнүгә бәйләнешле. *Классик белем алу.*

Классик көрәш — спорт көрәшенең төп халыкара төре. *Классик көрәш секциясенә язылу.*

КЛА'ССИКА *җыйг. и.* Классик II (1 мәгъ.) әсәрләр. *Классиканы уку.* □ *Музыкаль классиканың иң катлаулы, иң нәзакәтле репертуары да аның [Мәдинә] өчен һава шикелле үк зарур рухи азыкка әйләнде.* Ш. Хөсәенов. *Бу түгәрәк утырышларында [яшьләр] матур әдәбият, рус һәм Көнчыгыш классикасы белән танышалар.* А. Расих.

КЛА'ССИКАЛЫ *с.* Классик әсәрләре булган, классик әсәрләр иҗат иткән. *Әдәби традицияләр ягыннан да татар әдәбияты — шактый бай классикалы әдәбият.* Н. Юзиев.

КЛАССИФИКА'ТОР *и.* 1. Классификация ясаучы белгеч. *Минераллар классификаторы.*

2. *махс.* Минераль кисәкчекләрне зурлыгы, формасы, тыгызлыгы буенча кластарга аера торган аппарат. *Гидравлик классификатор. Конуслы классификатор.*

КЛАССИФИКА'ЦИЯ *и.* Предметларны, күренешләрне яки берәр өлкәгә караган төшенчәләрне нинди дә булса гомуми билгеләре нигезендә кластарга, төркемнәргә һ. б. бүлү, аеру системасы. *Мотоболны Бөтенсоюз бердәм спорт классификациясенә кертү.* □ *Г. Ибраһимов [әсәрләрендәге] --- социаль мотивларга бездә әле гыйльми рәвештә тукталынганы, аларга классификация ясалганы юк.* Г. Гали.

КЛАССИФИКА'ЦИЯЛӘУ *ф.* Классификация ясау. *Асиянең инде диссертация материаллары тупланган, кайбер анализларны кабат карап чыгып, классификациялисе калган иде.* Каз. утл.

КЛАССИЦИЗМ *и.* 1. XVII йөздән XIX йөзнең башларына кадәр сәнгатьтә, әдәбиятта антик үрнәкләргә ияреп эшләүгә нигезләнгән һәм ныклы эстетик канун-нар системасы белән бәйләнгән юнәлеш.

2. Белем бирү, укытуның борынгы грек, латин телләрен һәм антик әдәбиятны өйрәтүгә нигезләнгән системасы.

КЛАССЛЫ *с.* 1. Нинди дә булса өлкәдә (мәсәлән, машина йөртүдә, спортта һ. б.) бик яхшы хәзерлеге, осталыгы, тәжрибәсе булган. *Беренче класслы шофер.* □ *[Без] зур класслы спорт осталары белән мактана алмыйбыз әле.* Н. Дәүли.

2. Үз ишләре рәтендә эшләнү, эшкәртелү сыйфаты белән аерылып торган. *Беренче класслы магнитофон. Класслы фотоаппарат.* □ *— Гүзәл Юлдашева, ипташләр, - - - [чуенның] тагын да яхшырак сыйфатлысын, югары класслысын коеп бирде.* Н. Исәнбәт.

Класслы вагон — пассажир поездында иң яхшы җиһазландырылган вагон. *Класслы вагоннарның берсеннән ике офицер күренде.* И. Туктар.

КЛАССЛЫЛЫК *и.* Югары сыйфатлылык. *Терлекчелекнең төп продукциясе кыйммәте аның сыйфатын — көрлекне, сортлылыкны, майлылыкны, класслылыкны һәм башкаларны исәпкә алып билгеләнә.* Каз. утл. || Тәжрибәлелек, осталык. *Класслылыкны үстерү.*

КЛАССТАШ *и.* Кем белән дә булса бер класста укучы яки укыган кеше. *Гәрәй бәйрәмчә киенгән классташлары һәм кунаклар тулы зур якты бүлмәгә кердә.* С. Сабиров. || *с. мәгъ.* Кем белән дә булса бер класста укучы яки укыган. *Классташ укучылар. Классташ ипташне очрату.*

КЛЕ'ВЕР *и. к.* тукранбаш. *Кызыл клевер. Шуышма клевер.* □ *Бал кортлары клевер чәчәкләре өстендә кайнашалар иде.* Г. Галиев || *с. мәгъ. к.* клеверлы. *Без беренче бригаданың клевер көтүлекләренә килеп җитәбез.* А. Расих.

КЛЕ'ВЕРЛЫ *с.* Клевер үскән, клевер чәчелгән. *Яратам мин клеверлы кырда Тәмле бал исләре аңкуын.* З. Мансур. — *[Печәннең] клеверлырак җирен чап.* Ю. Әминов.

КЛЕЁНКА *и.* 1. Бер яки ике ягыннан да махсус состав белән капланып, су үткәрмәслек итеп эшләнгән тукыма. *Өстәлләрдәге клеенкалар искереп беткән.* Ш. Камал. *[Төргәкнең] эченнән саргаеп беткән хатлар, бер рәсем, клеенка тышлы ике дәфтәр килеп чыкты.* А. Шамов.

КЛЕЁНКАЛАУ *ф.* Клеенка белән тышлау (мәсәлән, ишекне).

КЛЕЁНКАЛЫ *с.* Клеенка ябылган, клеенка белән тышланган. *Клеенкалы өстәл. Клеенкалы ишек.*

КЛЕЙ *и. сөйл. к.* җилем. *[Кече як бүлмәдән] бербер артлы „артык-портык" нәрсәләр чыгарыла барды. Алар урының эш кораллары, такта, клей кебек нәрсәләр алды.* Г. Гобәй.

КЛЕ'ЙСТЕР *и.* Крахмалдан яки оннан хәзерләнгән җилем. *Крахмал клейстеры.* □ *Җилемләү өчен желатинны, агач җилемен, чия җилемен яки клейстер эремәсен файдаланырга мөмкин.* Робинзон эзл.

КЛЕ'ММА *и. махс.* Чыбыкларны (проводларны) машинага, приборга, аппаратка тоташтыру өчен эшләнгән махсус җайланма; винтлы кыстыргыч.

КЛЕПТОМАН *и. мед.* Клептомания белән авыручы. *Миңа күптән түгел бер клептоман турында сөйләделәр.* Соц. Тат.

КЛЕПТОМА'НИЯ *и. мед.* Урлашмыйча тора алмаудан гыйбарәт психик авыру.

КЛЕРИКАЛ *и. полит.* Клерикализм тарафдары; клерикаль партия члены. *Клерикаллар органы.*

КЛЕРИКАЛИЗМ *и. полит.* Капиталистик илләрдә, монополистик капитал файдасы өчен, илнең политик һәм культура тормышына, революцион һәм демократик хәрәкәтенә каршы көрәштә чиркәүнең һәм руханиларның йогынтысын көчәйтүгә юнәлтелгән реакцион политик агым.

КЛЕРИКАЛЬ *с.* Клерикализм позициясен яклый торган. *Клерикаль партия.*

КЛЕРК *и.* Кайбер Көнбатыш Европа илләрендә контора хезмәткәре. *Сугыш башында ул суд башкаручы конторасында клерк булып эшләгән.* Сов. әд.

КЛЕТЧА'ТКА *и.* Үсемлек күзәнәкләренең тышчасы составында була һәм кайбер промышленность тармаклары өчен чимал хезмәтен үти торган матдә; целлюлоза.

КЛЕТЬ *и. махс.* Шахтага төшү һәм күтәрелү өчен җайланма. *Беренче тапкыр клетька утырып шахтага [төштем].* Ф. Хөсни. *Камил клетька менеп баса, клеть күтәрелә башлый.* Һ. Такташ.

КЛӘШ *с. махс.* Түбәнгә таба киңәеп киткән чабулы (итәкле), балаклы. *Тулы кләш юбка.* □ *Егоров, - - - кләш чалбарын киң сары каеш белән буып, биленә зур парабеллум таккан.* И. Гази.

КЛИЕНТ *и.* 1. Борынгы Римда ярым хокуклы, хокук мөнәсәбәтләрендә үзенең яклаучысына—патронына бәйле булган гражданин.

2. Даими рәвештә килеп йөрүче, заказ биреп торучы, сатып алучы кеше. *[Шәрәфи агай], бер карт доктор үзенең клиентына караган төсле, Гарифка күз текте.* Ш. Камал. *[Габдулла бай] үзеннән бурычка товар алучы күптәнге клиентлары белән дә ачуланышты.* М. Галәү. || Нинди дә булса кредит, сәүдә яки промышленность оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган кеше яки учреждение. *Саклык кассалары клиентлары.*

3. Үз эшен алып баруны адвокатка, нотариуска һ. б. ш. тапшырган кеше. *Адвокат үзенең бу клиентын коткарып кала алмаган.* Соц. Тат.

КЛИЕНТУ'РА *җый. и.* Клиентлар (2, 3 мәгъ.). *Шәфи Алмаз - - - эшне дә [зурдан] йөртә белә. Клиентурасы да ни җитте түгел аның.* Ш. Маһнур.

КЛИ'ЗМА *и. мед.* 1. Дәвалау яки диагноз кую максаты белән туры эчәккә сыеклык җибәрү. *Клизма кую.*

2. Туры эчәккә сыеклык җибәрү өчен махсус прибор.

КЛИ'МАКС *и. мед. к.* климактерий.

КЛИМАКТЕ'РИЙ *и. мед.* Хатын-кызларда, 45—54 яшьләр арасында, женси бизләр эшчәнлеге үзгәрешенә бәйләнешле чор.

КЛИ'МАТ *и.* Билгеле бер урынга хас метеорологик шартлар. *Континенталь климат. Йомшак климат. Диңгез климаты.* □ *Кунаклар капитан каютасының ясалма климатында рәхәтләнеп утырдылар.* Р. Мостафин. || *с. мәгъ.* Климатка бәйләнешле. *Камбоджаның уңайлы климат шартлары күп төрле авыл хуҗалыгы культураларын үстерергә, алардан мул уңыш алырга бөтен мөмкинлекләрне бирә.* Каз. утл.

КЛИ'МАТЛАШТЫРУ *ф.* Яңа климат, тормыш шартларына җайлаштыру, күнектерү. *[Укучылар] башка климат зоналарындагы фәнни учреждениеләр белән элемтә урнаштырдылар, климатлаштыру өчен алардан төрле-төрле үсемлек орлыклары алдылар.* Сов. мәк.

КЛИ'МАТЛАШУ *ф.* Яңа климат, тормыш шартларына җайлашу (хайваннар, үсемлекләр турында). *Яңа урынга климатлашу.* || *күч.* Яңа урынга, мохиткә үзләшү (кешегә карата).

КЛИМАТО'ЛОГ *и. махс.* Климатология белгече.

КЛИМАТОЛО'ГИК *с.* Климатологиягә бәйләнешле. *Климатологик институт. Климатологик күзәтүләр.*

КЛИМАТОЛО'ГИЯ *и.* Климат төрләрен, аларның формалашуын, географик таралышын һәм органик тормышка тәэсирен өйрәнә торган фән.

КЛИНДЕР *и.* Төче камырдан бөжра формасында ясап пешерелгән күмәч. *Юлда клиндер сатучы хатын очрап, бәйләменә ун тиен сорады.* К. Нәҗми. *Без, җыйнаулашып утырып, клиндер белән чәй эчтек.* Ш. Маннур.

КЛИ'НИК *с.* Клиникага бәйләнешле. *Клиник шартлар.* || Клиникада үткәрелә, башкарыла торган. *Клиник дәвалау. Клиник тикшеренүләр.*

Клиник үлем — тереклек белән үлем арасындагы күчеш чоры. *Клиник үлем белән чын үлем арасында хәлиткеч дүрт-биш минут вакыт бар.* Г. Әпсәләмов.

КЛИ'НИКА *и. мед.* Авыруларны дәвалау белән бер үк вакытта студентлар практика үтә торган һәм фәнни тикшеренүләр алып барыла торган дәвалау учреждениесе. *Теш клиникасы.* □ *Авыруы җиңеләеп, тиздән тереләчәге мәгълүм булган көнне үк Шакир клиникадан чыгарга ашыкты.* Ф. Әмирхан.

КЛИНИЦИСТ *и.* Клиникада дәвалау эшләре белән бергә фәнни күзәтүләр һәм тикшеренүләр алып баручы врач. *Клиницист булса иде ичмаса,* [*Зәһит*] *бит теоретик кафедра вәкиле — физиолог.* А. Расих. *Атаклы клиницистлар тән белән күңелне бергә дәвалау бердәнбер дөрес метод икәнен практикада күрсәттеләр.* Г. Әпсәләмов.

КЛИ'НКЕР *и. махс.* **1.** Су үткәрмәүчән бик каты кирпеч (юлга түшәү, җәю өчен файдаланыла).

2. Аерым каты кисәкләр (ярымфабрикат) хәлендәге яндырып укмаштырылган цемент чималы.

КЛИ'НКЕРЛАУ *ф. махс.* Яндырып клинкерга әйләндерү. *Балчыктан ясалган әйберләрне клинкерлау.*

КЛИ'ПЕР *и. махс.* Тиз йөрешле, өч мачталы җилкәнле корабль.

КЛИШЕ *и. махс.* **1.** Типографиядә басу өчен металл, агач яки башка төрле тактага ясалган рәсем, сызык һ. б. ш. *Типографиядә гарәп хәрефләре юк, ә һәр хәрефнең клишесен ясау — ифрат мәшәкатьле эш.* Г. Гобәй.

2. *күч. кит.* Еш кабатлана торган, туйдырып бетергән фикер, штамп сүз һ. б. турында. *„Сәяр" труппасының уены һаман бер төстә, бер калыпта, бер рухтарак була иде. --- Бер-бер артлы куелган пьесалардагы рольләр тәмам клише булып беткәннәр иде.* Ш. Әхмәдиев.

КЛИШЕЛӘНҮ *ф. кит.* Калыплашу, штамплашу. [*Газетага*], *күбесенчә, әзер терминнар, клишеләнгән сүзләр белән эш итәргә туры килә.* Ш. Рамазанов.

КЛОА'КА *и.* **1.** Шәһәрләрдә шакшы су агызу өчен җир асты каналы. || Юынтыклар, шакшы сулар түгә торган чокыр; тиреслек, чүплек башы.

2. Пычрак урын, шакшы урын. || *күч. кит.* Бозык җәмгыять, бозык среда турында.

3. Кайбер хайваннарда (балыкларның бер төркемендә, барлык җир-су хайваннарында, сөйрәлүчеләрдә, кошларда һәм кайбер имезүче хайваннарда) сидек һәм тизәк юлларының бергә кушылган урыны; арткы юл.

КЛО'УН *и.* Циркта көлкеле номерлар башкаручы артист. [*Артистның*] *көлдергечлек ягы да цирк клоуннарыныкыннан бик түбән.* Ш. Камал. *Тамаша беткәч, аллы-гөлле ыштан кигән, бит очларына иннек яккан клоун Мәрьямгә кызыл шар бүләк иткән иде.* М. Маликова.

КЛОУНА'ДА *и.* Клоуннар катнашында башкарыла торган цирк уены. || Шундый уенга ияртемле мәзәк кыланыш. — *Чын сөйләшүне клоунадага әйләндердегез.* А. Гыйләҗев.

КЛО'УНЛАНУ *ф.* Клоуннарча кылану, шамакайлану. *Тар чалбарлы бер егет аеруча клоунлана. Өстендәге киемнәре үк бик мәзәк егетнең.* Р. Төхфәтуллин.

КЛО'УНЛЫК *и.* Клоун һөнәре. *Концертка кеше вәгазь тыңларга да килми, клоунлык күрергә дә килми; аларның икесенең дә махсус урыннары бар.* Ф. Әмирхан.

Клоунлык итү — клоунлану. [*Бикмөхәммәтевнең*] *яраннары да простой кешеләр түгел: кайсы доверенный, кайсы аның дулаган, кәефле чагында янында клоунлык итеп йөрүче ярлы якыны.* Ш. Камал.

КЛО'УНЧЫЛЫК *и.* Клоуннарга хас кәмитчелек. [*Артист Хуҗа ролен*] *--- гаять шома һәм матур алып бара. Тик кай урыннарда йөреш, кыланыш белән клоунчылыкка бирелү генә урынсыз.* М. Җәлил.

КЛУБ *и.* **1.** Бергәләп ял итү, күңел ачу, спорт белән шөгыльләнү һ. б. өчен билгеле бер даирә, профессия кешеләрен берләштергән җәмәгать оешмасы. *Шахматчылар клубы.* □ *Купецлар клубында буген „Ревизор" куелачак.* Ф. Әмирхан. *Казан әйтә: „Ничә төрле җәмгыять, Матбага һәм клублар, Мәдрәсәләр, мәктәпләр, Университетлар миндә бар".* Г. Камал. || СССРда, предприятие яки учреждениеләр каршында, культура-агарту эшләре алып бара, хезмәт ияләренең ялларын оештыра торган профсоюзлар карамагындагы оешма. *Мехчылар клубы. Химиклар клубы. Авыл клубларында культура-агарту эшләрен җанландыру.*

2. Шундый оешмалар урнашкан бина. *Бер ярты сәгатьтән соң инде без авыл уртасындагы бакчага салынган зур гына клубка барып кердек.* А. Шамов. *Яктылыкка баткан клуб әче, Матур җиһаз белән киенгән.* Ш. Маннур.

КЛУ'МБА *и.* Чәчәкләр үстерү өчен, гадәттә калку итеп, нинди дә булса йомык фигура формасында ясалган түтәл; чәчәклек. [*Балалар бакчасының ишек алдына*] *җиләк-җимеш агачлары утыртылган, чәчәк клумбалары ясалган.* М. Хәсәнов. *Фабрика ишек алдында бакча. Клумбада чәчәкле гөлләр.* Р. Ишморат.

КНЕХТ *и. махс.* Судно палубасында яки пристаньда буксир арканын бәйләп кую өчен хезмәт итә торган тәбәнәк куш багана (бүкән) формасындагы җайланма. *Илдус белән Асия* [*каекны*] *--- палубага күтәрә алмасалар да, көч-хәл белән кнехтка бәйләп куйдылар.* С. Сабиров.

КНО'ПКА *и.* **1.** Кәгазь, тукыма һ. б. ш. әйберләрне нинди дә булса каты нәрсәгә беркетү өчен эшләнгән киң эшләпәле, үткен очлы бик кыска кадакчык. [*Мансур*] *стенага дәү этисенең фоторәсемен кнопка белән беркетте.* Г. Әпсәләмов.

2. Бармак белән басып электр чылбырын ялгау һәм төрле механизмнарны хәрәкәткә китерү өчен җайланган төймә. *Сигнал кнопкасы.* □ [*Мохтар*] *бер кулы белән парадный ишеге тоткасына тотынып, икенчесе белән звонок кнопкасына басты.* Ш. Камал. [*Киләчәктә эшче*] *станокларның да күбесен, ихтимал, кнопкага басып кына әйләндереп җибәрер.* Г. Бәширов.

3. Ике кисәктән торып, берсе икенчесенә кереп берегә торган металл яки пластмасса каптырма. *Гөлчирә халат кнопкаларын берьюлы тартып ычкындырды.* Ф. Хөсни.

КНО'ПКАЛАУ *ф.* Кнопка белән (1, 3 мәгъ.) беркетеп кую.

КНО'ПКАЛЫ *с.* 1. Кнопкага (2 мәгъ.) басып хәрәкәткә китерелә, эшләтелә торган. *Кнопкалы звонок.*

КНЯГИ'НЯ *и.* Князь хатыны.

КНЯЗЬ *и. тар.* 1. Борынгы рус феодаль дәүләтендә гаскәр һәм аерым өлкә башлыгы. *Киев князьләре.* □ *Князь Игорь турындагы үлмәс Ялкынлы җыр яңгырый бүген дә.* С. Хәким.

2. Шундый кешеләрнең яки патша указы белән шул исем дәрәҗәсен алган кешеләрнең нәселдән нәселгә күчеп килә торган титулы. — *Безнең тирәдә,* — *ди* [*Җиһанша бабай*], — *мөселманнар үзләре - - - князьләр, мирзалар, коллар дип өчкә бүленеп йөртелеләр иде.* Г. Ибраһимов. *Князьнең төскә-буйга чибәр бер кызы булган.* Г. Гали.

3. *күч.* Революциягә кадәрге Россиядә татарларга карата көлеп-кимсетеп әйтелгән кушамат. *Хуҗа көлемсерәп кенә эшләпәсен кузгатты да* [*татар эшчеләренә*]: — *Д, князьләр икән... Яхшы халык... Яратам мин аларны, эшчән булалар...* — *диде.* Ш. Камал.

КНЯЗЬЛЕК *и.* 1. Князь тарафыннан идарә ителә торган өлкә. *Борынгы рус дәүләте князьлекләре. Мәскәү князьлеге.*

2. Князь титулы һәм хокукы. *Янгаличовның бабалары, үзләренең наданлыклары сәбәпле, - - - князьлекләрен җуйганнар.* Ф. Әмирхан.

КОАГУЛЯ'ЦИЯ *и. физ., хим.* Коллоид кисәкчекләренең зуррак кисәкләргә укмашуы һәм, койка сыман масса хасил итеп, коллоид эремәдән аерылып төпкә утыруы.

КОАГУЛЯ'ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Коагуляция хәленә килү, укмашу.

КОАГУЛЯ'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Коагуляция хәленә китерү, укмаштыру.

КОАЛИЦИОН *с.* Коалициягә бәйләнешле. *Коалицион хөкүмәт.* □ [*Мирзахан:*] *Без бит монархистлар түгел, коалицион социалистлар.* Т. Гыйззәт.

КОАЛИ'ЦИЯ *и. полит.* Уртак максатларга ирешү өчен дәүләтләр, партияләр арасында төзелгән килешү, берләшмә, союз. *Антифашистик коалиция.*

КОБА *с.* Аксыл, сыек көрән (хайван төсе турында). [*Булат:*] *Мулла, синең коба сыерың минем ала сыерымны сөзеп үтергән.* Т. Гыйззәт.

Коба кызыл — җирән кызыл. *Коба кызыл ат.* **Коба туры** — бурлы ат.

КОБАГА *и. диал.* Бәбкә таяна торган колакса башларына әйләндереп кагып чыгылган махсус калын тактадан гыйбарәт җепсә (аның астыннан кәрниз башлана). [*Йорт салучылар*], *бәбкә утыртып, гәрничкә тотынган булганнар. Ләкин кобагасын гына сугып чыкканнар.* Х. Сарьян.

КО'БАЛЬТ *и. хим.* 1. Тимердән катырак көмеш сыман ак металл. || *с. мәгъ.* Кобальттан ясалган.

2. Составында шушы металл булган куе зәңгәр төстәге металл. || *с. мәгъ.* Куе зәңгәр. *Кобальт төс.*

КОБЗ *и. махс.* Украинада думбра тибындагы элекеге музыка коралларының берсе.

КОБЗАРЬ *и.* Кобзда үзе уйнап җырлаучы Украина халык җырчысы. — *Украинаның бөек кобзаре Тарас Шевченко - - - үзен Днепр елгасы буена күмүләрен сораган.* Ш. Бикчурин.

КО'БРА *и. зоол.* Эссе якларда яшәүче, баш арты тимгелле, агуы бик көчле булган зур елан; күзлекле елан. *Алсу кобра.*

КОБУРА *и.* Револьвер, пистолет яки наган кынысы, кабы. [*Офицер*] *ашыкмыйча гына кобурасыннан наганын алды да Актүшкә төзәп атып җибәрде.* Г. Гобәй.

КОБЫС *и. иск.* Скрипка сыман борынгы кыллы уен коралы. *Ансамбльгә 6 корал кергән: кобыс, курай сыман ике корал, балалайка һәм ике бубен.* Каз. утл.

КОВБОЙ *и.* Атлы көтүче (АКШның көнбатыш штатларында). *Исәпсез-сансыз китап тышларында киң читле эшләпә кигән, ат менгән ковбойлар чабыша.* Р. Мостафин.

КОВБО'ЙКА *и.* 1. Ирләр өчен махсус өлге белән тегелгән шакмаклы күлмәк. *Менә күксел ковбойкалы егет, Нәрсә кайный икән аңында?* Х. Камалов.

2. Очлы түбәле, киң читле эшләпә.

КОВЁР *и. сөйл. к.* келәм. *Тыныч бүлмә. Трюмо. Картиналар. Ковер. Комод. Шунда гөл дә бар.* Ш. Мөдәррис.

КОВЕРКОТ *и.* Тышкы киемнәр өчен тыгыз, затлы йон тукыма. *Пальтолык коверкот.* || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Өстенә саргылт коверкот костюм кигән егет, үзенә текәлгән дистәләрчә күзләрне күргәч, азрак каушый калды.* С. Рафиков.

КОГО'РТА *и.* 1. *тар.* Борынгы Римда легионның уннан бер өлешен (якынча 600 кеше) тәшкил иткән отряд, хәрби берләшмә.

2. Уртак идеяләр, максатлар берләштергән кешеләр группасы. *К. Маркс һәм Ф. Энгельс - - - пролетар революционерларның данлыклы когортасын үстерделәр.* Соц. Тат.

КОД *и. махс.* Телефон, телеграф, радио һ. б. аша белешмәләр, сигналлар бирү өчен кулланыла торган шартлы кыскартмалар, билгеләр системасы. *Фельдфебель - - - төн буе радиоаппарат яныннан китмәде. Яшерен код цифрлары өзлексез шыкылдый торды.* Ш. Маннур.

КО'ДА *и.* 1. *муз.* Музыкаль пьесаның йомгаклау өлеше.

2. *әд.* Юл саны төгәл булырга тиешле әсәрләрнең, мәсәлән 14 юллы сонетның, ахырына өстәмә итеп бирелгән шигъри юл.

КОДА' [кода] *и.* 1. Өйләнәсе егет ягыннан кыз яучыларга, кәләш сорарга барган ир кеше, ир яучы. *Күрше кызына кода килгән, Нигә лә мине берсе дә сорамый.* Җыр. *Хәйрулла, үзенең олы малаена Юкәле авылыннан кыз килешкәндә, Вахит абзыйны - - - кода булып барырга чакырган.* М. Гали.

2. Өйләнешүчеләрнең берсенең атасы һәм ир туганнарына икенче якның ата-анасы һәм туганнары эндәшә торган туганлык атамасы. *Ике коданың катнашы күп, сыйлары уртак, уен-көлкеләре бергә бара.* Г. Ибраһимов. *Кода белән кодачаның кыска гына арада „әйтешеп" алулары - - - читтән карап торучы Мохтарга бик кызык тоелды.* Ш. Камал.

Кода төшерү *этн.* — зур туй үткәч, кызның әти-әнисен махсус рәвештә кунакка чакыру.

КОДАГЫЙ *и.* Өйләнешүчеләрнең берсенең анасы һәм аннан өлкән хатын-кыз туганнарына икенче якның ата-анасы һәм туганнары эндәшә торган мөрәҗәгать сүзе — туганлык атамасы. — *Улыңны өйләндереп-өйләндереп тә, кодагыең белән рәхәтләнеп барып-килеп йөрмәгәч, ни кызыгы бар.* А. Шамов. [*Галимә:*] *Миңа да кодагыйлар алдында киярга йонмы, сатинмы бер күлмәк ясамый килешмәс.* М. Фәйзи.

КОДА-КОДАГЫЙ *җый. и.* Кода белән кодагый булган кешеләр. [*Карт — Вахит белән Хөббигә:*] *Әйдәгез менә монда, кода-кодагый булып, түрдән узыгыз.* Г. Камал.

КОДА-КОДАГЫЙЛЫК *җый. и.* 1. Кода һәм кодагый мөнәсәбәтендә булу хәле.

2. *күч.* Эш урынында туган-тумачалык, эшнәлек бәйләнешләре нигезендә була торган урынсыз яклау-

лар, ташламалар. *Мәсәлләрендә [шагыйрь] кода-кодагыйлыктан көлә.* Г. Хуҗиев.

КОДАЛАУ *ф.* 1. *к.* яучылау 1. *[Кәримә] алдан кодалап йөргәч - - - бер аксак кызыл инвалидка кияүгә чыккан.* Г. Ибраһимов. — *Хәзрәт әйтә, яргыччы Шәйдүк кызын үзем кодалыйм, — ди.* Т. Гыйззәт.

2. Туй вакытында кода-кодагый буларак кунаклашу. *Әтинең күзләре шундый сөйкемле, йөзендә шундый куаныч балкый, әйтерсең, гомер буе шулай туйдан туйга күңел ачып, кодалап кына яшәгән.* Г. Бәширов.

3. *күч. сөйл.* Бик тырышып нәрсәдер эшләргә тәкъдим итү, нинди дә булса эшкә алынырга үгетләү. *[Назиров:] Макаров үзе [мине авылга китәргә] „кодалап" йөри.* Г. Әпсәләмов. — *Әтиең - - - оборона заводында эшли. Күптән түгел генә әле аны авылга „кодаларга" килгәннәр иде. Тимерчелеккә.* А. Шамов.

Кодалап йөрү, кодалый бару *этн.* — зур туй үткәннән соң, махсус чакыру буенча, егетнең ата-анасына кунакка бару. — *Я, ничек урман эше, Газзән абый? — дип сорады Газинур. — Эш — кодалый бару түгел, билгеле.* Г. Әпсәләмов.

КОДАЛАШУ *ф.* 1. Кодалык мөнәсәбәтләренә керү. *Ике гаилә арасында кодалашу дәвере үтте — билге дә бирелде, яраш туй да үткәрелде.* Каз. утл.

2. *күч. ирон.* Берәр нәрсә белән артык мавыгып китү. *Ак башлы белән кодалашу.*

КОДАЛЫК *и.* 1. Кода (1 мәгъ.) булу вазифасы; кодалау (1 мәгъ.) эше. *Танабугаларның өлкәннәреннән ике адәм, - - - асыл бүләкләр, алтын акчалар алып, Кызыл-Ком җәйләвенә кодалык белән киттеләр.* Г. Ибраһимов.

2. Кода (2 мәгъ.) булу. *Кодалык бүләге.* □ *Ат уйнатып, утыз көн уен, кырык көн туен кылып, ике ыруг кодалыкка кул бирештеләр.* Г. Ибраһимов.

КОДАЧА *и.* Өйләнешүчеләрнең берсенең ата-анасыннан яшьрәк хатын-кыз туганнарына икенче якның ата-анасы һәм туганнары эндәшә торган туганлык атамасы. — *Миңсылу, Фәтхулла хәзрәтләргә кодача тигәнлектән, аларга килгәли иде.* Ф. Әмирхан. — *Дәдә әле, Айсылу кодача, бер генә минутка кереп чык әле.* Г. Бәширов.

КОДЕИН *и. махс.* Ютәлне басу өчен кулланыла торган ак кристалл порошок. *Кодеин — көчле тәэсир итүче дарулар группасыннан.* Ш. Хөсәенов.

КО'ДЕКС *и.* 1. *махс.* Системалаштырылган һәм берәр өлкәгә карый торган законнар җыентыгы. *Хезмәт турындагы законнар кодексы.* □ *Болгарларда җинаять кодексы булган дигән мәгълүматлар да бар.* Каз. утл.

2. *кит.* Кешенең җәмгыятьтә үз-үзен тоту кагыйдәләре, гореф-гадәтләре җыелмасы. *Коммунизм төзүчеләрнең мораль кодексы.*

КОДРӘТ *и.* Көч, куәт. *Хәзер ул үзендә бер көч, бер гайрәт сизә иде, - - - хәтта, кирәк булса, бөтен тауларны, ташларны әйләндерергә кодрәте җитәр кебек тоела иде.* Ш. Камал. *Барысы да - - - кодрәтләреннән килгән хәтле тырышалар.* Ф. Яруллин. || *күч.* Тәэсир итә торган, үзенә нык җәлеп итә торган көч. *Сәнгатьнең нинди зур кодрәткә ия булуын [Зөфәр] бары менә - - - [бүген генә] күрде, аңлады, хәйран калды.* Ә. Еники. || *күч.* Йогынтылы көч. *Балыкчының күңел күзе ике башлы бөркет печатьле кәгазьнең кодрәте зур булуын тиз шәйләп алды.* Г. Минский.

КОДРӘТЛЕ *с.* 1. Көчле, куәтле. *Кодрәтле, киң җилкәле, имәндәй таза кеше, көчсезләчеп, Илсөярнең аяк астына ауды.* Г. Гобәй. *Ярлылар җыелышында булган бу көчле агым, бу кодрәтле ташкын һаман үсә иде.* С. Рафиков.

2. *күч.* Табигый булмаган, тылсымлы көчкә ия булган. *[Балалар] каршында укытучы абыйлары табигатьнең бөтен серләрен һәм бөтен тереклекнең телен белә торган ниндидер кодрәтле, зирәк кеше булып гәүдәләнә.* Г. Бәширов. | *хәб. функ. Миндә хәзер кеше ышанмаслык искиткеч корал бар. Көчле мин, көчле! Кодрәтле мин, кодрәтле!* Г. Кутуй.

КОДРӘТЛЕЛЕК *и.* Кодрәтле булу сыйфаты.

КОДРӘТЛӘНҮ *ф. сир.* Мактану, масаю, гайрәтләнү. *Әле һаман да [Корбангалинең] малае өчен кодрәтләнүе ишетелә иде.* Ф. Хөсни.

КОДЫК *и.* 1. *иск. к.* кое 1. *Төкермә кодыкка, суын эчәрсең.* Мәкаль. — *Ауууу! дип кычкырды. Бу кеше кәрван башы Вахит булып, аның болай кычкыруы кодыкка җиткәнлекне белдерү иде.* М. Галәү.

2. *диал. к.* бәке. *Кодык ую.*

КОЕ *и.* 1. Җирнең сулы катламыннан су алу өчен текә казылган (гадәттә жимерелмәс өчен стеналары агач бура белән буралган) тирән чокыр. *Кое казу. Кое суы. Сиртмәле кое.* □ *Озак та үтмәде, мөлдерәмә сулы чиләк кое авызыннан килеп тә чыкты.* Г. Гобәй.

2. *махс.* Гадәттә аергыч сүз белән килгәндә: төрле техник максатлар өчен казылган, бораулганган тирән чокыр. *Берничә җирдә нефть коеларының вышкалары, кадап куйган шикелле, югары озаеп торалар.* Ш. Камал. *Бу кыскарак вышкалар элек үк бораулап үткән шул җир асты коесын яңадан килеп ремонтлау өчен кирәк.* Р. Төхфәтуллин.

◊ **Кое казу** — кемгә дә булса начарлык эшләргә йөрү. *Кешегә кое казыма, үзең төшәрсең.* Мәкаль.

КОЕЛДЫК *и.* Коелган орлык, жимеш (артык өлгерүдән, җил-давыл белән һ. б. сәбәпләр аркасында). *Алма коелдыкларын җыю.* □ *Кырдагы иген коелдыгы зарарлы: аңа һәртөрле иген корты ияләшә.* Г. Хәсәнов.

КОЕЛМА *и.* 1. Эретеп махсус формага агызганнан соң алынган металл кисәге. — *Ни өчен коелмаларны җыйнаграк, шомарак эшләп, металлның йомычкага чыгуын киметмәскә?* Соц. Тат.

2. Коеп эшләнгән әйбер. *Тимер-бетон коелмалары.* □ *Беренче вакытларда товарларны алмашканда акча турыдан-туры көмеш яки алтын коелмасы төсендә йөргән.* Политэкономия.

КОЕЛУ I *ф.* 1. Түгелү, чәчелү (бөртекле, вак, таралучан кисәкләрдән торган әйберләр турында). *Коел, коел, ярма, Безгә булыр бар да.* К. Нәҗми. *Юлның читендә чаналардан коелып калган салам һәм печән җәелеп ята.* Ә. Фәйзи. *Түшәмнән шыбырдап ком коелды.* Г. Әпсәләмов. || Таралу, яву. *Жимерелгән шәһәр яна дөрләп, Кайный төтен, корым коела.* Ф. Кәрим. || Вак кисәкләргә ватылып чәчелү, сибелү. *Бомбалар шулкадәр якын төшеп шартлыйлар, - - - өйләр дөрселдәп торалар, анда-санда исән калган тәрәзә пыялалары чылтырап тротуарга коелалар иде.* Г. Гобәй.

2. Күпләп өзелеп, аерылып, йолкынып төшү; түгелү, сибелү (яфраклар, чәч, йон, өлгергән жимеш, орлыклар һ. б. ш. турында). *Алма чәчәге коела Таңда искән җил белән.* Җыр. *Кызу урак чагы; ашлык коелып бара.* Г. Ибраһимов. *Йоны бик еш коелса да, бүренең холкы үзгәрми.* Мәкаль.

3. Күпләп төшү, төшеп бетү (теш турында). *[Картның] тешләре коелып беткән, эчкә батып калган авызының иреннәре калтырандылар.* Ф. Әмирхан.

4. Агу, агып тору, түгелү; ташу (сыеклыклар, күз яше, яңгыр турында). *Күзләрдән яшь коелу.* □ *Яңгыр - - - яфраклардан муенга коела, башка коела, күлмәкләрне манма су итеп тәнгә сылый.* Г. Ахунов.

5. Ясалу, коеп эшләнү. *Аэропланнар гади алюминнан коелыр!* Һ. Такташ. *[Госманның] чәнчә бармагын-*

да кашы йөрәк төсле итеп коелган көмеш йөзек ялтырый. Ф. Хөсни.

6. *күч.* Мул булып, бөркелеп таралу (яктылык, нурлар, хуш исләр турында). *Сирень чәчәкләреннән хуш исләр коелу.* □ *Көлтәләп күктән нур коела.* С. Сөләйманова. || *күч.* Ишетелү, яңгырау (тигез, салмак сөйләшү, җыр, музыка авазлары турында). *Тургай җыры якты күк йөзеннән, көмеш чыңнардай, чылтыр-чылтыр коела иде.* Г. Бәширов.

7. *күч.* Бер-бер артлы каян да булса чыгу, кая да булса килү (кешеләр турында). *Хәлим урамда күренү белән, барлык капкалардан малайлар коела башлады.* И. Гази. || Күбәүләп бер-бер артлы сикереп яки егылып төшү (арбадан, чанадан, машинадан һ. б.). *Ак битле, елтыр күзле „чүлмәкләр" [малайлар] көлешә-көлешә чанадан коелдылар.* И. Гази. *Кешеләр шыбырдашып [машинадан] җиргә коелдылар.* Н. Фәттах.

8. *күч.* Атылу, чәчелү (йолдызлар турында). *Йолдызлар коелып торган Кышкы төн иде.* Ф. Кәрим.

9. *күч.* Кайбер фигыльләр урынына кулланылып, шул фигыльдән аңлашылган эш-хәлнең интенсив һәм дәвамлы булуын белдерә. *Докладчыга төрле яктан сораулар коелу.* □ *Аннан соң урманнар, елгалар, сәяхәтләр турысында сүзләр башланып, бер-бер артлы коелдылар.* Ф. Әмирхан.

10. *күч.* Юкка чыгу, бетү. *Икеләнеп торулар бөтенесе коелды.* Ф. Хөсни.

◇ **Коелып төшү (иңү)** — **1)** бик нык куркып китү, куркудан калтырап тору. *Әле күптән түгел генә үзен һәрнәрсәгә хаклы хуҗа итеп сизгән ерткыч табигатьле комендант, партизаннар кулына эләккәч, тәмам коелып төште.* А. Расих. — *Кешене куркытты бит соң, абау, билләһи, коелып иңдем!* М. Гали; **2)** бик нык каушау, югалып калу (оялудан, уңайсызланудан). *Кеше алдында, мәйдан каршында берәр эш башкарырга булса, коелам да төшәм оялудан.* Ш. Маннур; **3)** берәр сәбәп белән, аякта басып тора алмыйча, кинәт чүгәләү, егылып китү. *Бандит, йомшак кына ыңгырашып, тез өстенә коелып төште.* Ш. Камал. **Коелып эшләү** — тырышып, бирелеп эшләү. *Шулай итеп, мин колхозчы хәзер, --- Коелып эшләп йөри хатын да.* Ш. Маннур.

КОЕМЧЫ *и. иск.* Алтын-көмештән йөзек-беләзекләр коючы, ювелир. *Кызлар артыннан йөрүче коемчыга еш йөрер.* Мәкаль. *Алтынны саррафтан сора, җәүһәрне — коемчыдан.* Мәкаль.

КОЕН *и. диал.* Коеп яуган көчле яңгыр; *русчасы:* ливень.

КОЕНДЫРУ *ф.* **1.** Юындыру, сафландыру өчен суга кертү. [*Зәйтүнәләр*], *шау-гөр килеп, малайны коендыралар.* Ф. Хөсни. *Атларны да кыргычлап, чистартып, коендырып кайтырга кирәк.* М. Гали.

2. Мул итеп юешләү, чылату. *Куе кара болытлар, бөтенләй түбәнәеп, шәһәрне яңгырга коендырырга әзер булгандай үтеп тоталар.* Г. Ибраһимов. *Дулкын, су читендәге ташларга бәрелеп, Маратны баштанаяк коендырды.* Г. Гобәй. || Мул итеп пычрату, буяу, күмү турында. *Тузанга коендыру.* □ *Машина, Санияне пычракка коендырып, бик кызу гына узып китте.* М. Шабай.

3. Мул итеп тарату, күмү, чолгап алу (яктылык, нурлар, хуш исләр турында). *Һавага ракета күтәрелеп, бөтен тирә-якны җансыз ак яктылыкка коендырды.* Г. Әпсәләмов. *Август таңы көмеш нуры белән Коендырды күксел тауларны.* Г. Хуҗиев. *Берсеннән-берсе узышып үскән имән, юкә, өрәңге, әлмә агачлары --- безне салкын урман һавасы белән коендыралар.* М. Әмир.

4. *күч.* Кайбер фигыльләр урынына кулланылып, шул фигыльдән аңлашылган эш-хәлнең көчле, интенсив булуын белдерә. *Безнең сугышчылар [дошманны] пуля яңгыры белән коендыралар.* А. Әхмәт. *Әйтерсең лә әллә ни эшләгән: мине рәхмәтләр белән коендыралар гына.* Ф. Хөсни.

КОЕНТЫ *и. сөйл.* Коелып, түгелеп-чәчелеп калган нәрсәләр. [*Лапас астында*], *коентыларны чүпләштереп, ике үрдәк йөри.* А. Гыйләҗев.

КОЕНУ *ф.* **1.** Юыну, йөзү, чуму; су керү. *Коену костюмы.* □ *Эсселәп китсәк, су коенабыз, судан ялангач көйгә комга чыгып ауныйбыз.* М. Гали. *Уйсу җиргә су җыела, Шунда казлар коена.* Җыр. [*Нуруллин*], *ваннага чыгып, коенып керде.* А. Шамов. || Юешләнү, чылану (мәсәлән, яңгыр астында). *Юлда ике рәт чанам йөзде, әйберләрем дә коенып алды.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Көзге имән яфраклары яңгырда коеналар.* Ф. Кәрим. || Нинди дә булса сыек, сибелеп, таралып торучы әйбер эченә керү, чуму, күмелү. *Нигез туфрагында тавыклар коена.* И. Гази. *Әнә, юлның йомшак тузанына кырын ятып, канатларын җилпи-җилпи, кыр чыпчыклары коена.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Күмелү (кояш, ай һ. б. дан килгән яктылыкка, нурга). *Озак та үтмәде, бөтен ындыр табагы һәм кырыйда тезелешеп торган чүмәләләр аксылзәңгәр нурга коенды.* Г. Бәширов.

КОЕШ: кан коеш — сугыш, үтереш. — *Тиздән --- бөтен дөнья хезмәт иясенә сугышсыз, кан коешсыз туганлык ватаны ясарбыз.* Т. Гыйззәт.

КОЖАН *и.* Күннән, брезенттан, клеёнкадан һ. б. шундый су үткәрми торган әйберләрдән тегелгән пальто. *Паларусов балавызлы киндер кожанын --- [чөйгә] элде.* Г. Ибраһимов. *Ишектән өстенә сары кожан --- кигән юл кешесе килеп керде.* Г. Бәширов.

КО'ЖАНКА *и. сөйл.* Күн куртка, пальто.

КОЖИМИТ *и.* Күнгә охшашлы, күнне алыштыра торган материал. *Кожимит табанлы ботинка.*

КОЖУХ *и. тех.* Корылмаларны, механизмнарны яки аларның частьларын саклап, каплап тора торган тышча (тышлык), футляр. *Броня тишкеч пуля пулеметның кожухын ватты һәм көпшәсен кәкрәйтте.* Ш. Маннур.

КОЗАУ *и.* Туздан яки карама кайрысыннан эшләнгән (гадәттә цилиндр формасында) савыт; тырыс. [*Төлке:*] *Койрыгыма козау бәйләп бәкегә тыгып тордым да, балыклар үзләре козауга кереп тулдылар.* К. Насыйри.

КОЗГЫН *и. зоол.* **1.** Тын, аулак урыннарга оя ясый һәм һәртөрле азыкны ашый торган елтыр кара каурыйлы зур кош. *Козгыннар алар үлек күп җирдә булалар.* А. Шамов. *Һавада зираттан урманга очып килүче карт козгынның үзәк өзгеч шөбһәле тавышы яңгырап ала.* М. Мәһдиев.

2. *күч.* Кеше көчен, малын үзләштереп, талап яшәүче (эксплуататор сыйныф вәкилләре — эре хуҗалар, кулаклар, дин әһелләре һ. б. турында). [*Мәхмүт:*] *Директоры да шул инде аның: бер ояның козгыннары. Анысы инде аның ата козгын.* Ш. Камал. — *Теге, мәчет козгыны [Җиһанша хәзрәт], канга тоз салды, бәдбәхет.* Г. Минский.

3. *күч.* Дошман самолётлары турында. *Сугышның беренче җәендә, --- кинәт әллә кайдан фашист козгыннары килеп чыгып, комбайнны бомбага тоттылар.* Г. Гобәй.

◇ **Козгын тавышы** (кешегә карата) — ямьсез, ягымсыз тавыш. *Үги ананың иң яхшысыннан да козгын тавышы килә.* А. Әхмәт.

КОЗЫК *и. диал.* Эрбет чикләвеге. *Нарат җилләген, торна-күзне, козыкны, карагатны [монда] ат йөге белән ташыйлар.* Ш. Маннур.

КОЗЫРЁК *и.* Баш киемендә (фуражка, бүрек, картуз һ. б. ларда) маңгай өстенә чыгып торган ярым түгәрәк формадагы чыгынты. *Кепка козырёгы.* □ [*Җыенда*] *картуз козырёгы өстенә ялтырап торган җиз эмблема кадап куйган --- кеше дә бар иде.* Ф. Хөсни.

КОЗЫРЁКЛАУ *ф.* **1.** Хәрби хезмәткәрләр арасында: уң кулны баш киеменә — чигә янына күтәреп сәламләү. *Журумский капитан Гилёвка барып, кулларын бот буена ябыштырып (фуражка булмагач, козырёкларга ярамый), үзенең, артта калып, арьергардлык хезмәте үтәвен белдерде.* А. Таһиров.

2. *рәв. мәгъ.* **козырёклап.** Козырёк сыман итеп, алга чыгарып. — *Сөт ярата ул, сөт эчертерсең яме, кызым, — дип киңәш бирде яулыгын козырёклап бәйләгән рус карчыгы.* Г. Ахунов.

КО'ЗЫРЬ *и.* **1.** *к.* уен 5. — *Простой белән козырьны ябалармыни?* Г. Коләхметов.

2. *күч.* Нинди дә булса максат өчен файдаланырга уңайлы очрак, хәл, мөмкинлек. *Рәхим иң соңгы козырьдан файдаланырга уйлады: ул үзенең сөекле остазы профессор Герасим Павлович Андрияновка шалтыратырга булды.* А. Расих. — [*Мине гаеплә өчен*] *бернәрсәне козырь итмәкчеләр: янәсе, мин морза нәселеннән.* Э. Касыймов.

◇ **Козырь тузы** — бай, дәрәҗәле, абруйлы кеше турында. *Ә бит аның да* [*Биктаһир картның*] *козырь тузы булып йөргән чаклары бар иде.* И. Гази.

КОЙГЫН *с. сөйл.* Коеп ява торган. *Койгын яңгыр.*

КО'ЙКА *и.* Бер кешелек гади төзелешле тимер карават (больницада, тулай тораклта, казармада һ. б.). *Җәмали белән янәшә койкада күзен бәйләгән бер егет ята иде.* М. Гали. *Пароход палубасына тыгыз итеп койкалар тезелгән.* Г. Бәширов.

КОЙКА' [қойқа] *и.* Озак кайнатылган аяк-тояк яки сөяк шулпасына (саркындысына) вак кына ит яки балык кисәкләре катнаштырып, суытып куертылган салкын ашамлык. — *Бозау аякларын мунча мичендә генә өтәрсең. Койка куярбыз, койка, килен... шул калтыравыкны үлеп яратам инде.* С. Рафиков. *Зур-зур савытлардагы тавык, күркә түшкәләре, койка һәм башка нигъмәтләр авыздан су китерә.* Каз. утл.

КОЙКАЛАУ [қойқалау] *ф.* Койкалык (2 мәгъ.) салып, койка эчендә калдырып суыту (пешкән итне, балыкны һ. б.). *Койкаланган дуңгыз баласы. Койкалап хәзерләнгән балык.*

КОЙКАЛЫК *с.* **1.** Койка ясау өчен хәзерләнгән; койкага җитәрлек. *Койкалык аяк-тояк.*

2. *и.* Койка ясау өчен хәзерләнгән шулпа (саркынды).

КОЙМА I *и.* Нәрсәне дә булса аерып торган яки әйләндереп алган ныгытма, корылма. *Такта коймa. Читән коймa. Киртә коймa. Утыртма коймa.* □ *Госманны койманың теге ягында калдырып, үзем коймa аша төштем.* Ф. Хөсни. *Йортны урап алган коймалардан чебен дә үтәрлек түгел.* Р. Ильяс.

КОЙМА II *с.* Коеп ява торган, бик көчле. *Төньяк Сахалинда коймa яңгырлар башланды.* Ә. Маликов.

КОЙМАК *и.* **1.** Сыек камырдан табада пешерелгән йомшак чәй яны ашамлыгы. *Ачы коймак. Төче коймак.* □ *Карчыкның самовары кайнаган, майлы коймаклары пешеп өлгергән иде.* Г. Ибраһимов. *Кайда коймак — шунда кунак.* Мәкаль.

2. *сөйл.* Су өстендәге түгәрәк майлы (мазутлы) таплар. *Малай су өстендәге аллы-гөлле нефть „коймакларына" карады.* И. Гази.

3. Яссы ташны су өстеннән чәпчетеп аткан вакытта барлыкка килгән вак түгәрәк дулкын.

Коймак кою — коймак пешерү. *Кешеләр коймаклар коялар, кабартмалар пешерәләр, малайларына яңа күлмәкләр тегәләр.* И. Гази.

◇ **Коймак ашау** — атылган яссы ташның су өстеннән, вак түгәрәк дулкыннар хасил итеп, берникадәр сикереп баруы турында. — *Аннан суга таш атып уйнадык. ---* [*Зифа апа*] *да атты. Аныкы коймак ашады, безнеке ашамады.* Г. Гобәй.

КОЙМАКЛЫ *с.* Янына коймак бирелгән. *Егет коймаклы чәйне яратмый торган тискәре кеше булып чыкты.* А. Шамов. — *Сугыш вакытында парлы мунча белән коймаклы чәй буламыни ул?* М. Гали.

КОЙМАЛАУ *ф.* Нәрсәне дә булса коймa белән аеру, әйләндереп алу. *Коймалап чыгу.* □ *Йорт урам яктан коймалап алынган иде.* Н. Фәттах.

КОЙМАЛЫ *с.* Коймa тотылган, коймa белән әйләндереп алынган.

КОЙРЫК *и.* **1.** Хайван гәүдәсенең арткы өлешендәге (гадәттә хәрәкәтләнә торган) өстәмә үсенте яки хайван гәүдәсенең очлаеп беткән арткы өлеше. *Ат койрыгы. Елан койрыгы. Балык койрыгы.* □ *Сыерлар, яртылаш су эченә кереп, өсләренә кунган кигәвеннәрне койрыклары белән кугалыйлар.* Ә. Айдар. *Тиен дә койрыктан уңган: сикерсә — пружинадай булган, йокласа — юрган.* А. Алиш. || Гәүдәнең арткы өлешендә бер учма каурыйлар (кошларда). *Әтәч койрыгы. Саескан койрыгы.*

2. *күч.* Оча торган аппаратларның очлаеп беткән арткы өлеше. *Самолёт, --- койрыгын труба төсле күккә күтәреп, борыны белән карга чумды.* С. Баттал. || Гомумән нәрсәнең дә булса арткы өлеше, арткы ягы, арткы бетеме. *Пароходның койрык ягында ышык һәм җылы иде.* М. Әмир. *Бурлаклар, сал койрыгындагы көймәгә төялеп, ярга чыгалар.* М. Гали. *Исхак, буа койрыгынарак барып, ялгызы гына чиркәнчек алырга, йөзеп карарга булды.* А. Гыйләҗев. || Бербер артлы тезелеп киткән яки тезелеп барган төркемнең арткы өлеше. *Колоннаның башы үзәнлеккә төшеп бара, ә койрыгы бөтенләй күренми дә.* Г. Әпсәләмов. [*Кыям*] *газета киоскысы янына җитте дә ярты кварталга сузылган чиратның койрыгына килеп басты.* И. Гази.

3. *күч. кимс.* Иярчен (эштә, сүздә, карашта кемгә дә булса иярүче); куштан, ялагай. *Безне куркырлар дип көткән кулаклар һәм аларның койрыклары ишетсеннәр: без чигенмәбез дә, өрекмәбез дә.* Г. Гобәй. *Гыйльметдин белән генә эш бетте дип тынычланy дөрес булмас, аның койрыклары бездә тагын булырга тиеш әле.* Ә. Еники.

4. *күч. сөйл.* Нинди дә булса эш, бурыч һ. б. ш. ның үтәлеп бетмәгән, төгәлләнмәгән өлеше, ахыры. *Туйның койрыгы һаман дәвам итә әле.* Каз. утл. *Яхшы эшнең башы бул, яман эшнең койрыгы да булма.* Мәкаль. || Укучылар, студентлар телендә: „2" ле билгеләр, үз вакытында тапшырылмаган зачетлар, имтиханнар, контроль эшләр һ. б. [*Бер укучы Шәкүр турында:*] *Элек койрыкларын бетерсен, аннары уйлап карарбыз.* Г. Галиев.

5. Ашлык җилгәргәндә аерылып чыга торган начар сыйфатлы ач бөртекләрдән, вак башаклардан, чүп орлыклардан һ. б. ш. гыйбарәт катнашма. — *Әткәй, әллә инде картая башлагансың, --- шундый ашлы койрык калдыргансың.* Ф. Бурнаш.

6. *диал.* Бәрәңге бакчасы арты; йортның ындыр ягы. *Галимә апа, --- һәр көнне дип әйтерлек, үзебезнең койрыктагы елга буена төшә.* М. Гафури.

7. *махс.* Киндер сугу станында буй җепнең көредән соң күшәгә кадәр тараеп барган өлеше.

8. *күч. сөйл.* Кеше исемен белдерә торган кушма сүзнең беренче яки икенче кисәге. [*Шакиржан:*] *Бу,*

Сәхибгәрәй абзый малайларын әйтәм: берсе дхмәтгәрәй, икенчесе Мөхәммәтгәрәй иде, бусы кайсы икән? [*Галимә:*] *Гәрәй инде.* — *Ул бит коры гына Гәрәй. Безнең татарда һәр кешенең исеменә нинди дә булса бер койрык тагыла.* Т. Гыйззәт. || Кеше исеменә (аның һөнәрен, характерын һ. б. ачыклау, аерымлап күрсәтү өчен) ялгап, кушып әйтелә торган өстәмә сүз яки кушамат. *Авыл халкы да, „Мәҗит хәлфә" дип, минем исемгә койрык тагып йөртә башлады.* М. Гафури.

Койрык сөяге *анат.* — кеше умыртка сөягенең очлаеп беткән түбәнге өлеше (тоташып үскән 4—5 умырткадан гыйбарәт). *Койрык сөягемне күргәнем юк та, торам әле.* Мәкаль. **Койрык тоту** — көймә, сал хәрәкәтенә тиешле юнәлеш бирү (махсус руль яки койрык ишкәге ярдәмендә). *Илдар ише, Сания койрык тотты.* Г. Гобәй. *Киң Иделнең буенда баржа тарттым, Сал өстендә койрык тоттым мин.* Җыр. **Койрык чөе** — киндер сугу станында күшәнең күзен киертеп куя торган агач.

◊ **Койрык астына су керү (ут кабу)** *гади с.* — эш тыгызга килеп, кыен хәлгә калу турында. — *Койрык астыңа ут кабынса, кабалану түгел, бүре булып уларсың.* С. Сабиров. **Койрыгын бору** — бик каты кисәтү; берәр төрле чара күреп, тәртипкә кертү, тәртипләндерү (кешегә карата). — *Эшчеләр үзгәрде. - - - Сәбәбе бер: барлык участокларда да* [*кышын учак җылысын, җәен күләгәне яратучыларның*] *койрыкларын бордылар.* А. Гыйләҗев; **Койрыгын кыскарту (кисү)** — нинди дә булса ярамаган эшкә чик кую. [*Шәйхулла дхмәткә, янап:*] *Койрыгыңны тиз кыскартырмын.* Д. Аппакова. **Койрыгын тоту** — 1) озак эзләп очрату, күрү. [*Мораташев:*] *Берүзеңә ике камыт кигәч, синең койрыгыңны тотып булмый.* С. Рафиков; 2) *к.* койрыкка басу. — *Минем койрыкны тоту бик җиңел әйбер түгел.* Ш. Камал. **Койрыгын төйнәү** — берәр эшне тәмамлау, түгәрәкләү. *Разия, өйдә табак-савыт юып, күзгә күренмәс вак-төяк эшләрнең койрыгын төйнәгәннән соң, чоланга урын җәеп керде.* С. Рафиков. **Койрыгыннан бару** (кемнең дә булса) — берәр кешегә, политик группага иярү, шуның карашын, политикасын яклау. *Патша һәм борынгы министрлар төшерелеп, алар урынына шуларның койрыкларыннан бара торган кешеләрнең эш башында утыруларыннан гына революция бул*[*мый*]. М. Гафури. **Койрык бозга кату** — берәр кешегә яки урынга ихтыярсыз бәйле булу. [*Шәйхи Солтанга:*] *Юк инде, тиз генә Казанга ычкына алмассың хәзер, хәзер синең койрык бозга каткан.* А. Расих. **Койрык болгау (бутау)** — 1) ялагайлану, куштанлану. — *Менә монда чыгып сөйләүче кешеләр, - - -* [*байлар, алпавытлар, фабрикантларның*] *мәнфәгатьләрен саклар өчен, шуларга койрык болгап, безне һаман да кан түгәргә өндиләр.* М. Гафури; 2) алдашу, икейөзлеләну, хәйләләү. *Моңарчы Җиһангир тирәсендә койрык болгап, дуслашып йөргән Фәйзи бар.* Г. Ибраһимов. **Койрык бору** — 1) алдашу, хәйләләү; үзен тоттырмаска тырышу. *Гыйльманов сөйләгән арада Фәтхи: „Хәйләкәр малай, кара син аны, ничек итеп койрыкны бора!" — дип күңеленнән кичерде.* Ш. Камал; 2) әйткәненнән кире кайту. *Бары да, Баһавиның „койрыкны боруын" күреп, шаркылдап көлеп җибәрделәр.* А. Расих; 3) нәрсәдән дә булса куркып, кире китү, качу. *Совет самолётлары күренү белән, немец машиналары койрыкларын бордылар.* М. Әмир. **Койрык булу** — иярү, фикердәш булу. — *Сез шул шайкага койрык булып йөрисез.* Г. Ибраһимов. **Койрык булып** — 1) бер-бер артлы тезелеп. *Озын койрык булып сузылган вагоннарны сөйрәгән поездлар станциягә килеп-китеп кенә торалар.* С. Рафиков; 2) арттан иң ахыргы булып. *Асылгәрәй отряд обозына койрык булып ялганды.* М. Шабай. **Койрык күтәрү** *гади с.* — масаю, эреләнү, кылтаю. *Садыйк карт әченнән: „Дидә, малайның бераз койрыгы күтәрелсен!" — дип уйлап куйды.* Ш. Камал. **Койрык чәнчү** *гади с.* — каян да булса әйтмичә, сиздермичә генә китү; качып китү. [*Дтиләр*] *Тажи абзыйны да үзләре янына эшкә чакырганнар иде, ә ул койрык чәнчеде.* Ш. Маннур. **Койрыкка басу** — 1) арттан куып җитү, эзләп табу. *Казанда гына туктарга исәбе юк* [*Сәфәргалинең*], *чөнки чамалый: эзне ераккарак яшермәсәң, Сәлмәннекеләрнең койрыкка басулары бар.* Ф. Кәрим; 2) эштә, укуда һ. б. куып җитү, ярышта калышмау турында; 3) кемнең дә булса явыз эшчәнлеген тиешле чаралар күреп туктату, фаш итү. *Егет бөтен сугыш буена ОРСны имеп яткан бит, бу юлы койрыгына басарлар.* Ә. Еники. **Койрыкка сөйрәү (өстерәү)** — эшкә, эшне алга алып барырга комачаулау, тоткарлык ясау. — *Аюкин кебек кешеләр колхозны койрыкка өстери.* С. Рафиков. **Койрыкка тагылу (ябышу)** — 1) арттан калмыйча иярә йөрү. [*Абыстай Җәләлгә:*] *Соң, илаһым, барсаң, барып идең. - - - Мин койрыгыңа ябышмас идем.* Г. Ибраһимов; 2) иярү (нинди дә булса эштә, карашта). — *Без койрыкка тагылырга барыбыз да әзер, башлап җибәрүче юк — менә бәла кайда.* И. Гази. **Койрыкны бот арасына кыстыру** *гади с.* — куркып калу, шүрләү; дәшми-тынмый гына йөрү. — *Койрыкларын бот араларына кыстырдылармы? Тыннары да чыкмый малайларның!* Ш. Камал. **Койрыкны кысу** — 1) тыйнаклану, артык башбаштакланмау. [*Залимханның*] *улы да шундый ук залим иде. Ләкин бусы бераз койрыгын кыса төште.* Г. Гобәй; 2) күрку, шүрләп калу. — *Эшкә килеп терәлгәч, бар да койрык кысты.* Р. Ишморат. *Песи күргәч, күселәр Койрыкларын кыстылар.* М. Җәлил; 3) башбаштакланырга ирек бирмәү, мөмкинлекләрен чикләү. — *Хәзер инде* [*кулакларның*] *койрыкларын кыса башладылар.* С. Рафиков. **Койрыкны сыртка салу** — качып китү, читләшү (эштән, авырлыктан һ. б. куркып). — *Ярый әле, вакытында акылыма килеп, баш исән чагында койрыкны сыртка салып ычкынырга өлгердем.* Э. Касыймов. **Койрыкны тоттырмау** — 1) хәйләләү, оста ялганлау, оста эш итү. [*Сәлим*] *койрыкны тоттырмаска тырыша бугай.* Ш. Камал; 2) хәл итүе, чишүе катлаулы, ачыкланып җитмәгән берәр эш, мәсьәлә турында. [*Сөләйман абзыйның*] *фикерендә әлегә койрыгын тоттырмый торган, ләкин ниндидер бик мавыктыргыч очкын бар кебек.* Г. Әпсәләмов. **Койрыкны яшереп (төйнәп) йөрү** — нинди дә булса яшерен яки явыз ниятле эшне сиздермәслек итеп башкару турында. [*Кулакларның*] *тактикасы билгеле: койрыкларын яшереп йөриләр.* Ф. Сәйфи-Казанлы. — *Койрыгыңны төйнәп йөр, улым.* С. Рафиков. **Койрыкны җыю** — 1) үз вакытында эшләнеп бетмәгән эшләрне җиренә җиткереп эшләп бетерү. — *Ул хәбәр* [*газетада*] *чыкканчы, без, бәлки, койрыкларны җыеп та өлгерербез.* Ф. Хөсни; 2) җинаять эзләрен яшерү. **Койрыкта сөйрәлү (бару, булу)** — барысыннан да артта бару, артка калу (нинди дә булса эштә яки карашта). *Оппортунистлар - - - вакыйгаларның койрыгында сөйрәлделәр.* В. И. Ленин. — *Безнең алтынчы рота сугышларда башкалардан калышмаган шикелле, бу эштә дә койрыкта булмас.* Ш. Усманов.

КОЙРЫКЛАНУ *ф.* **1.** Койрык үсү.

2. Койрык сыман нәрсә барлыкка килү. *Комета койрыклану.*

3. *күч. сөйл.* Бер-бер артлы тезелеп басу (чиратта). *Сәмигулла аларның* [*кибетләрнең*] *кайсына барма-*

сын, койрыкланып тезелгән озын-озын чыратлар күрде. С. Рафиков.

4. *күч. сөйл.* Ялганып, җанланып китү (сүз, әңгәмә). *Сүз койрыкланып барганда гына, өяздән килгән агитатор --- мәҗлесне ачык итеп игълан итте.* Һ. Такташ.

КОЙРЫКЛАП *рәв. күч.* 1. Боргалап, бизәкләп. *Начальник бер генә секундка күтәрелеп карады да, сырлы-мырлы койрыклап, кул куюын дәвам иттерде.* С. Рафиков.

2. Арттырып, булмаганны өстәп, үзеннән кушып. *Габделхәй кинаяләп, койрыклап --- сөйләргә ярата.* Ш. Камал.

КОЙРЫКЛЫ: койрыклы йолдыз — *к.* комета. *Бик күп җирдә койрыклы йолдыз күргәннәр, ул халыкка яңа афәтләр киләсенә икән, дип сөйләделәр.* М. Галәү.

◇ **Койрыклы сүз** — кинаяләп әйтелгән сүз. [*Галләмнең*] *койрыклы сүзләрендә үзалдына бертөрле икейөзлелек аңкый иде.* Ш. Камал.

КОЙРЫКСЫЗ *с. күч.* 1. Ышанычсыз, үз фикерендә (сүзендә) нык тормаучан. *Койрыксыз адәм.* || Нигезсез, фактлар белән расланмаган. — *Мондый койрыксыз караш фәнни булмый.* К. Тинчурин.

2. *сөйл.* Кыска (кием турында). [*Зөләйха улы Зыяга:*] *Кайдан тапкансың шул җыен койрыксыз киемнәреңне.* Г. Ибраһимов.

КОЙРЫКЧЫ *и.* 1. Руль ярдәмендә көймә, судно хәрәкәтенә юнәлеш бирүче кеше. *Кинәт көчле давыл дулкынны Таушалдырып бәрде көймәгә. Койрыкчы да, ишкәкчеләр дә Һәлак булды, давыл юк итте.* М. Җәлил. *Александр Терентьевич аңа Халит урынына [пароходта] койрыкчы булып эшли торырга кушты.* С. Сабиров.

2. *күч.* Койрыкчылык тарафдары. *Бу теория [„тактика-процесс" теориясе] исә безнең оппортунистларның койрыкчылар дигән кушаматын беркетте.* В. И. Ленин.

КОЙРЫКЧЫЛЫК *и.* Асылда эшчеләр сыйныфының революцион бурычларын, аның политик һәм экономик таләпләрен чикләүгә, революцион көрәштән баш тартуга, революцион партиянең эшчеләр хәрәкәтендәге җитәкчелек ролен инкяр итүгә кайтып кала торган оппортунистик идеология һәм тактика. *Революцион пролетариат --- бергәләрнең аяныч койрыкчылыгын һәм икенчеләрнең революцион фразасын үзеннән себереп түгәчәк.* В. И. Ленин.

КОЙТЫ *с. сөйл.* Начар, яман. — *Эшләр койтырак иде шул ул чакта.* Каз. утл. || Ямьсез; холыксыз, эшәке (кешегә карата). *Үзең койты булгач, көзгене хурлама.* Мәкаль. *Яхшыга тормыш юк, койтыга үлем юк.* Мәкаль. || Арык, хәлсез, кечкенә (хайван турында). *Теге төтен озынлыгы кеше койты биясе белән бер кат бүренең өстеннән таптатып чыгарды.* Әкият.

КОЙТЫЛАНУ *ф. сөйл.* Начарлану. [*Юлда*] *дүртме, бишме көн барсак та, телгә алырдай яңалык булмады. --- Тик тамак ягы гына койтыланды.* Ш. Маннур.

КОК *и.* Суднода аш пешерүче, ашчы. *Кичке чәйгә кок минем исем-фамилиямнең баш хәрефләре язылган --- торт пешереп китерде.* Р. Мостафин.

КО'КА *и. бот.* Калын яфракларыннан кокаин алына торган тропик куак.

КОКАИН *и. махс.* Кока яфракларыннан алына торган агулы матдә (авыруны киметү өчен һәм наркотик буларак кулланыла). *Кокаин иснәү.* □ *Оста теш докторы --- элек уртларыгызга кокаин җибәреп бернәрсә сизмәслек хәлгә китерә, аннан төбе-тамыры белән куптарып чыгара.* К. Нәҗми. *Иван Николаевич морфийдан, кокаиннан башка тора алмый иде.* Ш. Еникеев.

КОКАИНИЗМ *и. к.* кокаинчылык.

КОКАИНЧЫ *и.* Кокаин куллануга бирелгән кеше; наркоман. [*Бу кеше*] *казарма муштрасын үткән берәр авантюрист поручик кисәге һәм, өстәвенә, кокаинчы булса кирәк.* Н. Исәнбәт.

КОКАИНЧЫЛЫК *и.* Кокаин куллануга һәвәслек — наркоманиянең бер төре. || Кокаин күп кулланудан организмның агуланыу белән бәйләнешле психик авыру.

КОКА'РДА *и.* Махсус кабул ителгән өлге буенча эшләнеп, формалы баш киеменә (фуражкага, бүреккә) беркетелә торган түгәрәк яки озынча металл значок. [*Тангатаров*] *уянып китсә, алдында озын урыс: кокарда куелган фуражкалы, кылычлы, мылтыклы.* Г. Ибраһимов. *Бил каешының тимерен, шинель төймәләрен, бүректәге кокарданы чистартырга --- [кирәк].* Ф. Хөсни.

КОКА'РДАЛЫ *с.* Кокарда беркетелгән. *Өсләрендәге кара күлмәк, лампаслы күк чалбар, --- кокардалы фуражкалары аларның ак казаклар икәнлеген белдереп тора иде.* Ш. Усманов. [*Җирдә*] *кокардалы яшел каска ята.* М. Җәлил.

КОКЕ'ТКА *и.* 1. *махс.* Күлмәк, блуза кебек киемнәрнең иңбаштан күкрәк турысына кадәр итеп киселгән өлеше, кыска кыса (шуңа киемнең калган өлеше ялгап тегелә). *Кокеткага җыерып утырту өчен [күлмәкнең] арка ягының киңлеген арттырырга кирәк.* Йорт эшләре.

2. Кием-салымы, кыланышлары белән кемгә дә булса ошарга, үзенә игътибарны җәлеп иттерергә тырышучы, гомумән көязләнергә яратучы хатын-кызга карата әйтелә. *Тукай хатын-кызлар мәҗлесен, төрле кокеткаларның, „телсез студентларның" сүзләрен тәмсез, күңелсез, кирәксез эш дип кенә атый.* Каз. утл. *Кокеткага дамаларның чырык-чырык көлүләре ишетелеп тора* Ф. Әмирхан.

КОКЕ'ТКАЛАП *рәв.* Кокетка (1 мәгъ.) ясап. *Күлмәкне кокеткалап тегү.*

КОКЕ'ТКАЛЫ *с.* Кокетка (1 мәгъ.) ясап тегелгән. *Кокеткалы күлмәк.*

КОКЕ'ТКАЛЫК *и.* 1. Кокеткага (1 мәгъ.) дип билгеләнгән материал.

2. Кокеткага (2 мәгъ.) хас сыйфатлар. *Бу — Әсманың коры бер кокеткалыгы, коры бер низыдыр.* Ф. Әмирхан.

КОКЛЮШ *и.* Балаларда көчле йөткерү белән үтә торган йогышлы авыру; бума ютәл.

КОКЛЮШЛЫ *с.* Коклюш белән авырый торган. *Коклюшлы бала.*

КО'КОН *и. к.* кузы II. *Ефәк коконы.*

КОКОС *и. к.* кокос пальмасы.

Кокос мае — кокос чикләвегеннән алынган май. **Кокос чикләвеге** — кокос пальмасының җимеше. *Синдбад җирдән берничә кокос чикләвеге җыеп ала.* Мең дә бер кичә. **Кокос пальмасы** – бик эре чикләвек формасындагы җимешләр бирә торган, божра-божра кәүсәле, каурый сыман яфраклы пальма. *Шикәр камышы басулары, кокос пальмалары арасында балчык өйле кечкенә авыллар, төрле-төрле тары басулары күзгә чалынып кала.* М. Мәхмүтов. **Кокос сөте** — кокос чикләвеге эчендәге әчкелтем, бераз эремчек суын хәтерләтә торган сөт сыман сыеклык. *Кокос сөтендә витаминнар, аксым һәм май күп. Ул сусынны гына басып калмый, ә туклыклы да.* Р. Мостафин.

КОКО'ТКА *и.* Буржуаз-дворян җәмгыятьтә: үзенә гашыйк булган ирнең исәбенә яши торган җиңел холыклы хатын-кыз.

КОКС *и.* Ташкүмер, торф һ. б. чималлардан махсус рәвештә һава кертмичә кыздырып хәзерләнгән каты ягулык. *Домна коксы. Кою коксы. Химик реакцияләрдә кокс куллану.* □ *Бер көнне [шахта хуҗалыгында] кокс төйибез, икенче көнне электр станцасында шлак түгәбез.* Ш. Маннур.

КО'КСЛАУ *ф.* Кокска әйләндерү. *Күмерне кокслаганда аерылып чыга торган газлар.*

КОКТЕЙЛЬ *и.* Төрле аракы төнәтмәләре, виноград шәрабләре, коньяк, ром, сок, җиләк-җимешләр, йомырка, бал, мороженое катнашмаларыннан торган исерткеч яки тәмле (десерт) салкынча эчемлек. *[Айзат белән Чәчкә] өч йомарлам мороженое ашадылар, салам белән сөт коктейле суырдылар.* Г. Мөхәммәтшин. — *Безнең „Восток"та, бөтен нәрсә булса да, коктейль булмый торган иде.* Р. Төхфәтуллин.

КОЛ *и.* **1.** Барлык хокуклардан һәм җитештерү средстволарыннан мәхрүм ителгән, үз хуҗасы — колбиләүченең милке саналган кеше; колбиләүчелек җәмгыятендә изелүче сыйныф вәкиле. *Коллар восстание се.* □ — *Кол базары ачык! Сезнең алдыгызда Фракия коллары. Болар кичә генә Римга каршы сугышучылар.* Н. Исәнбәт. *Егетне күрүгә, теге хатын һәм кол кызлар үкереп елап җибәрделәр.* Әкият. || Иске Россиядә крепостной крестьян. *Ат иярдән, кол боярдан качар.* Мәкаль. *Кар башына кар җитәр, Би башына кол җитәр.* Мәкаль.

2. *күч.* Тулысынча (экономик, политик һ. б. ш.) бәйле, ирексез, хокуксыз кеше турында. *Дөньядагы барлык кол халыклар Сөеп карый данлы илемә.* Э. Исхак. *Мин кол монда, йортсыз-ирексез; Ирексез һәм илсез — мин үксез.* М. Җәлил.

3. *дини.* Аллага буйсынган кеше, бәндә. *Ул тагын аллага ялварды: — Йа хода, үземә тапшырдым! Дошманның кара ниятен ерак кыл да дусларның изге ниятен юлдаш ит мин колыңа!* Г. Минский.

4. *күч.* Үзенең иреген, эшләрен тулысынча кемгәдер, нәрсәгәдер буйсындырган, шуңа бик нык бирелгән кеше. *Хисләр колы.* □ *Бай акча өчен елый, Чөнки ул акча колы.* Г. Камал. — *Күрсәтмәләр колы булуны ташларга вакыт, минемчә.* С. Рафиков.

◇ **Кол булу** — буйсыну, кол (2 мәгъ.) хәленә төшү. *Юк, без фашистларга кол булмабыз.* Э. Ерикәй. — *Гашыйк Шаһтимер, --- көтүченең кушуына кол булып, җилкәсенә чыбыркы элеп, куйлар көтә.* М. Фәйзи. **Кол итү** — кол хәленә төшерү; буйсындыру. *Басып керде дошман илебезгә, Кол итәргә безне, таларга.* Ә. Исхак.

КОЛА *с.* Кара койрыклы һәм кара яллы аксыл җирән (ат төсе турында). *Зур арбага безнең кола ат җигелгән.* Г. Ибраһимов. *Аттан ала да туа, кола да туа.* Мәкаль.

Кола ялан (сахра) — ачык, буш урын, тигез җир. *Эшчеләр, --- очлы кәйләләре белән чукый-чукый, без эшли торган шахтаны да бер-ике ай эчендә кола яланга әйләндерделәр.* М. Гафури. *Әле кичә генә әрем сабаклары тирбәлгән кола яланда --- мүкләп йорт күтәрәләр.* А. Гыйләҗев.

КОЛАК *и.* **1.** Кешеләрдә һәм умырткалы хайваннарда ишетү органы. *Эчке колак.* □ *Колак белән тыңла, башың белән уйла.* Мәкаль. *Колакка микрофон аркылы гади тавыш килде.* Э. Айдар. *Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә.* Г. Тукай.

2. Ишетү органының колак тишеге тирәсендәге тышкы, кимерчәкле өлеше; тышкы колак. *Маһруй --- яулыгын бәйләми генә колак артына каерып куйган.* М. Фәйзи. *Җамали куяннарны, колакларыннан тотып берәм-берәм карап, санап үз капчыгына сала.* А. Әхмәт.

3. *сөйл.* Колакчын (баш киемендә). *Газинур --- бүреген көязләндереп, кыңгыр салып кигән, бүтәннәр кебек колакларын төшереп бәйләмәгән.* Г. Әпсәләмов.

4. Төрле әйберләрдә тотарга, элеп куярга һ. б. уңайлы булсын өчен эшләнгән җайланма, колак сыман чыгынты. *Чиләк колагы.* □ *Әби әллә ничә җиренә ямау салып бетергән кечкенә генә самовар колагына барып тотына.* Г. Гали. || Гомумән колак (2 мәгъ.) сыман булып торган (яки күренгән) чыгынты. *Көннең никадәр салкын булуын кояш үзе әйтеп тора: аның ике ягында — ике колак.* Ә. Еники.

5. Яңа гына борынлап чыккан үсемлектә пар яфрак. *Углан яшьтән, тары колактан беленер.* Мәкаль.

Колак алкасы — колак йомшагына тага торган асылма бизәнү әйбере. *[Заһирә:] Мин синең урыныңда булсам, [сөенчегә] көмеш колак алкамны да кызганмас идем.* К. Тинчурин. **Колак бөтеркәсе** — колак эчендәге бормалы кимерчәкләр. *Колак бөтеркәләрендә җил шаулый.* Д. Аппакова. **Колак ите, колак йомшагы** — колак яфрагының аскы итләч өлеше. *[Камәрнең] бөдрәле чәче колак йомшагына җиткереп киселгән.* Г. Ибраһимов. **Колак мендәре** — кечкенә мендәр. *Баш астына, кемнеңдер капчыгыннан алып, колак мендәре куйдылар.* Г. Мөхәммәтшин. **Колак пәрдәсе** *анат.* — тышкы ишетү юлын урта колактан аерып торган яры, элпә. **Колак яфрагы** — тышкы колак. *Сәгыйть колак яфракларына кадәр кызарды.* Г. Минский. **Колак тешләтү** *этн. иск.* — бала вакытта, булачак кәләш билгесе итеп, малайдан кызның колагын тешләтү (ике якның ата-аналары килешүе буенча). *[Лаля:] Минем колагымны тешләтеп, вәгъдәләтеп куярга аларның ни хакы бар.* М. Фәйзи.

◇ **Колагы озын** — *к.* озын колаклы. — *Син мине, кәрван сарайда утыра да бернәрсә ишетми, дип уйлыйсың, ахры. Минем колаклар озын бит.* Ш. Усманов. **Колагы үзе белән** — кемнең дә булса тыңлап торуыннан, ишетүеннән сак булырга кирәклекне искәртеп әйтелә. *Бу төнне кычкырып җырлау түгел, кычкырып сөйләшергә дә ярамый. Немецның колагы үзе белән.* Ф. Хөсни. **Колагына (да) кермәү** — илтифат итмәү, тыңламау. *Ахры, кечкенә вакытта мин үзем дә кирәк булганмыдыр инде, ничектер, әнинең үгетләве минем колагыма бер дә кермәде.* М. Гали. *Зариф үзенең җиңелү хурлыгын да сизмәде, бу көлү дә аның колагына кермәде.* Г. Ибраһимов. **Колагына киртү (киртләү, киртекләү), киртеп кую** — бик нык кисәтү, онытмаслык итеп әйтү. — *Һәдиянең колагына киртеп куйыйк: әгәр --- ялган таратып, ара бозып йөри икән, --- фермадан кудырабыз.* Ә. Еники. *Сәлихҗан абзый боларның барысын да бик иплэп кенә --- дгъзам энекәшнең колагына киртеклэп кайта.* Р. Төхфәтуллин. **Колагына төшерү (тишү, салу)** — 1) алдан әйтеп кую, искәртү, кисәтү. *Мондый күршеләргә каршы көрәшүе җиңел булмаячагын --- алдан ук колакка төшереп куйганнар иде.* Каз. утл.; 2) кемгә дә булса барып сөйләү, эләкләү. *Хәлимәнең төнлә капка төбендә рус егете белән утырганлыгын күрүчеләр булган һәм моны Фазылҗан агайның колагына төшергәннәр.* Ш. Камал; — *Рәхилә бәгете турында Габделхак колагына кем тишкән икән?* И. Туктар. **Колагың ишетсен** — яхшылап тыңла, исеңдә тот (кисәтеп әйтү). *[Габделбәр Асылгәрәйгә:] Колагың ишетсен: моннан соң яланга аяк басасы булма.* М. Шабай. **Колагыңны кисеп (йолкып) кулыңа тоттырыр** — бик үткен, усал, чая кеше турында. *Бу хатын мәлҗерәп тора торган-*

нардан түгел. Колагыңны йолкып кулыңа тоттырыр. Җаена торсаң гына кеше. Б. Камалов. **Колак артыннан (артка) җибәрү; колак аша (яныннан) уздыру** — игътибар итмәү, җавапсыз калдыру. *Гыйльмановның бу юлы үзенә төбәлгән шактый җайсыз сүзләрне колак артыннан җибәрүе Сәмигуллинга беркадәр гажәп тоелды.* Ш. Камал. — *Кайбер нәрсәләрне колак яныннан уздырып җибәргәндә дә ярар иде.* Ф. Хөсни. **Колак асмау** — игътибар итмәү, тыңламау. *Ишняз башта бабайның сүзләренә колак асмады.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Колак бору** — берәр төрле гаеп, җитешсезлек өчен тәнкыйть итү, каты ачулану. [*Нәфисә:*] *Телефонга ашыгам. Мансуров чакыра. --- Колакны борырга чамалыйдыр.* Г. Бәширов. **Колак белән тыңламау** — яхшылап, игътибар белән тыңламау. [*Гөлҗиһан асраулар турында:*] *Сүзне һич колаклары белән тыңламыйлар.* Г. Камал. **Колак (итен) ашау (кимерү, чәйнәү)** — бер үк нәрсә турында туктаусыз искә төшереп бәйләнү, тиргәү, туйдырып бетерү. *Карчык та, --- колхозга әз эшлисең дип, колак итемне ашап кына тора иде.* Р. Ишморат. [*Минһаҗ — хатынына:*] *Син дә монда килеп бәйләнеп йөрмә әле, өйдә колак итемне чәйнәгәнең дә җитәр.* К. Әмири. — *Безгә юл кем күрсәтер? Мылтык бармы? — дип,* [*Шакир*] *минем колагымны кимерде.* Г. Ибраһимов. **Колак ишетмәгән; колак ишетмәгән, күз күрмәгән** — беркайчан булмаган, искиткеч. *Илебездә колак ишетмәгән Бөек гигантларны корабыз.* Н. Баян. *Колак ишетмәгән, күз күрмәгән Ялганнарны безгә тагалар.* Һ. Такташ. **Колак йомып утыру (яту)** — һичнәрсә белән кызыксынмау, гамьсез булу. [*Сөләйман абзый:*] *Киңәш кирәк икән, миңа килегез, Матвей Яковлевичка. --- Кыскасы, колакларыгызны йомып ятмагыз.* Г. Әпсәләмов. **Колак кагу** — 1) нәрсәдәндер мәхрүм булу, кулдан ычкындыру, буш калу. *Яраткан кызыңнан колак кагу җиңел эшмени ул!* Ш. Камал; 2) *дини.* азан әйткәндә, кулларны колаклар янына күтәреп, аллага буйсыну, коллык белдерү. *Алла колак какканны, түрәләр тәкбир әйткәнне ярата.* Мәкаль. **Колак катылану (кату)** — начар ишетү, саңгыраулану. — *Дөресен әйткәндә, операциядән соң колак та катыланып киттем.* Л. Гыйльми. — *Минем, контузиядән соң, колак катып калды.* Ә. Фәйзи. **Колак салу** — 1) тыңлау, тыңлап тору. *Колак салдым: эткәй белән әнкәй чаршау артында пыш-пыш сөйләшәләр.* Г. Ибраһимов; 2) игътибар итү; кызыксыну. *Кем соң колак салыр зарыма, Хәбәр итәр сөйгән ярыма.* Д. Аппакова. *Дошман китергән хәбәргә колак салма.* Әйтем; 3) игътибарга лаеклы, файдалы дип кабул итү. *Ибраһим Гази, үз-үзенә гаять таләпчән булу өстенә, ипташларчә тәнкыйть фикеренә дә чынлап колак сала белә торган язучы.* М. Әмир. **Колак салып (биреп) тыңлау** — игътибар белән тыңлау. *Мин аның сүзен бик колак салып кына тыңлап тордым.* М. Гали. **Колак сасыту (тынчыту)** — бер үк нәрсә турында сөйләп туйдырып бетерү. *Лагерь радиосы герман армиясенең „гүзәл җиңүләре" турында колакны сасытып бетергән иде инде.* Г. Әпсәләмов. — *Тукта инде, зинһар, нәрсә ул кадәр шаулыйсың, колагымны тынчытып бетердең.* А. Шамов. **Колак селкетеп утыру** — сүзгә, бәхәскә катнашмау, әндәшмичә тик утыру. — [*Нурмөхәммәт*] *ишәк төсле колакларын селкетеп тик утырамы?* Ш. Камал. **Колак сөенчесе этн.** — кызны кияүгә бирергә ризалык булганнан соң, кыз һәм кияү егетенең ата-аналары арасында алышабирешә торган вәгъдә бүләге. — *Ул кадәр күп мәһәр сорый торган булсалар, мин колак сөенчесе алышырга риза түгел.* Г. Камал. **Колак тону** — саңгырауланну, ишетми башлау. *Көчле туп тавышларыннан колаклар тону.* **Колак чыңлау** — колакта берәр төрле авырту, шаулау тавышы сиземләнү-тоелу турында. *Гайниҗамалның нәрсәдәндер колаклары чыңлап торган шикелле була.* Ш. Камал. **Колак шомарту (шомрайту, шәмрәйтү)** — усалланып яки бик каты чапҡанда колакларны артка таба яткыру (ат турында). *Атлар, колакларын шомартып, ачуланып,* [*Гавриловның атын*] *тешләп алалар.* А. Шамов. *Кечерәк кенә чаптар ат, колакларын шомартып, танауларын киереп, саженьнан саженьга атылып, мәйданга килеп тә керде.* М. Гали. **Колак яргыч** — бик көчле (тавыш турында). *Мина тавышы кебек колак яргыч тавыш ишетелде.* Г. Әпсәләмов. **Колакка алу (элү)** — тыңлау, истә тоту. — *Әгәр дә синең сүзләреңне колакка алучы булса, ни эшләр идең?* М. Әмир. *Иптәш минем сүзләремне колагына элеп тора.* Г. Насрый. **Колакка (да) алмау (элмәү)** — бөтенләй тыңламау, ишетергә дә теләмәү. [*Зыя Газизгә:*] *Атагызның һичбер сүзен колагыгызга алмыйсыз.* Ф. Әмирхан. *Мәйпәрвәз ханым иренең кисәтүен, бәлки, колагына да элмәгән булыр иде.* Ә. Еники. **Колакка барып ирешү (җитү)** — ишетелү (хәбәр, сер һ. б.). *Бу кара гайбәт дошманнар аркылы Кадыйр байның да колагына барып ирешә.* Г. Ибраһимов. *Ни әйтсәң дә,* [*бу эш*] *авыл башлыкларының колагына җитүе бар.* Г. Мөхәммәтшин. **Колакка каты (авыр)** — чукрак, начар ишетүче. *Солдатның колакка каты икәнен төшенгән Илдар шактый кычкырып* [*җавап бирде*]. Г. Гобәй. **Колакка керү (кереп калу)** — 1) аз гына хәтердә калу, сакланы. *Әнинең: „Буыннарымның сызлавы җелекләремә төште ләбаса", — дип зарланган сүзләре колагыма кереп калган.* М. Шабай; 2) ишетү, ишетеп калу (очраклы рәвештә генә). — *Бәлки колагыгызга да кергәндер: сезнең бу якларда, кайбер кантоннарда дигән сүзем, саранча бик котыра башлаган.* Ф. Хөсни. [*Бу сүз*] *ничектер бүген колагыма кереп калган иде дә, мин әһәмият бирмәдем.* Ә. Еники. **Колакка керерлек сүз** — эшлекле, игътибарга лаеклы сүз. — *Колакка керерлек сүз бу, кем, Хәйрулла энем.* М. Хәсәнов. **Колакка мамык (чүбек) тыгу, колаккаком тутыру** — ишетмәскә тырышу, тыңламау, игътибар итмәү. — *Бу кем дим телефонда, кем сөйли? --- Әллә колагыңа чүбек тыктыларымы?* Ш. Мөхәммәдев. *Ачуы чыккан днисә аны: „Йөрисез шунда сарыклар шикелле, колагызга ком тутырганмы әллә?" — дип тиргәргә тотынды.* Г. Әпсәләмов. **Колакка сак** — 1) тиз ишетүчән, ишетү куәсе яхшы; 2) саңгыраурак, ишетү куәсе начаррак. — *Исемем зиһеникамал булса да, соңгы елларда зиһенем саегып китте. Колакка да саграк.* Г. Мөхәммәтшин. **Колакка салып (киртеп) кую** — хәтердә, истә тоту. — *Колагыңа тагын бер нәрсәне салып куй: большевиклар бер нәрсәдән дә курыкмыйлар.* М. Шабай. — *Тормышта барысы да син уйлаганча гына бармый, улым. Моны колагыңа киртеп куй.* Ф. Яруллин. **Колакка тегеләйрәк** — *к.* колакка сак 2. *Хафиз бабай белән гәпләшүләр Бара авыр, китә озакка, Йөзгә җитеп, аннан узгандыр — Тегеләйрәк бераз колакка.* Ш. Мөдәррис. **Колакка туку** — кат-кат әйтү, исенә төшереп тору. *Бер-берегезгә юл куегыз дип, әтиләре* [*уллары*] *колакларына тукып кына тора иде.* М. Гали. **Колакка чалыну (сугылу)** — ишетелү, ишетелеп калу (сүз, хәбәр, сөйләшү һ. б. ш.). *Өстәлем күрше генә булганлыктан, кеше сүзен тыңлау ярап бетмәсә дә, аларның сөйләшүе колагыма чалына торды.* Г. Мөхәммәтшин. *Кызы белән әхнәфнең яратышулары турындагы хәбәрләр әледән-әле аның колагына сугыла торды.* С. Рафиков. **Колакка яту** — нәрсәнең дә булса унай тәэсир итүе; ошау, мәгънәле булу. [*Бу сүзләрнең*] *берсе дә Хәйретдингә аңлашылмый һәм аның кола-*

гына ятмый. М. Гали. — *Баядан бирле гармонеңны кыйкылдатасың, ә колакка ятарлык бернәрсә дә чыгара алмыйсың.* Х. Җәмил. **Колакка ятышлы** — аңлашылы, кирәкле, мәгънәле. *Колакка ятышлы сүзләр сөйләү.* **Колакка уткер (җитез)** — тиз ишетүчән, ишетү куәсе яхшы. *Сафа сүзгә саран булса да, колакка бик җитез иде.* А. Шамов. **Колаклар (үрә) тору** — 1) бик нык гаҗәпләнү (көтелмәгән хәлдән, хәбәрдән һ. б.). *Егетләрнең колаклары торды: бусы ни тагын?* Ә. Еники. *Әхмәтнең колаклары үрә торды. Секунд эчендә күңеленә әллә нәрсәләр килеп китте.* Ш. Камал; 2) бик нык кызыксынып тыңлый башлау, әсәрләнү. *Искедән калган язулар, китаплар дигәч, Карл Федоровичның колагы торды.* М. Гали. **Колакларны торгызу** — 1) сагаю, сагаеп калу, уяулану. *Маллар, ашый торган җирләреннән башларын күтәреп, колакларын торгыздылар.* Г. Ибраһимов; 2) игътибарны нык җәлеп итү, бик нык кызыксындыру. *Бу таныш көй һәм таныш сүзләрнең беренче юллары тыңлаучыларның колакларын торгызды.* Г. Әпсәләмов. **Колакларны торгызып** — игътибар белән, кызыксынып. *Без [Зиннәтнең] шатлыклы хәбәрләрен колакларыбызны торгызып тыңладык.* М. Гафури. **(Үз) колакларына (үзе) ышанмау** — чиктән тыш гаҗәпләнү (көтелмәгән берәр нәрсәгә). *Бу вакытта нинди елау?.. дминә бераз вакыт үз колакларына ышанмады.* Ф. Әмирхан. **Колактан китмәү** — колакта берәр төрле тавыш тою, ишетелгәндәй, яңгырап торгандай булу. [*Кызларның*] *көмеш чыңлавы кебек саф вә нечкә көлү тавышлары һаман колагымнан китми иде.* Ш. Камал. **Колактан сөйрәп чыгару** — көчләп, ихтыярсызлап чакыру, мәҗбүр итү. *Була шундый җыелышлар, анда инде ораторларны колакларыннан сөйрәп чыгаруның һич кирәге юк.* Р. Төхфәтуллин. **Колактан узу** — „зур үстеңме?“ дигән сорауга җавап формасында шаяртып әйтелә. — [*Айсылу*] *бик зур кеше булды инде, --- колагыннан узды.* К. Әмири.

КОЛАККА-КОЛАК *рәв.* **1.** Башкаларга ишеттермичә, пышылдап кына. [*Мәстүрә белән Рәян*] *икәү колакка-колак сөйләшәләр.* Г. Коләхметов.

2. *сөйл. к.* башма-баш.

КОЛАКЛАНУ *ф.* **1.** Колак сыман чыгынты барлыкка килү. *Ай колаклану.* □ — *Әнә, кара әле, бүген кояш та колакланып чыккан.* Г. Бәширов.

2. Яңа борынлап чыгу, ике нәфис яфрак җибәрү (үсемлекләр турында). *Кыярлар колаклану.*

КОЛАКЛАУ *ф.* Колак (4 мәгъ.) ясау. *Чиләкне колаклау.*

КОЛАКЛЫ *с.* **1.** *сөйл. к.* колакчынлы. *Хәйбул колаклы бүреген салып ук куйды.* Ш. Камал. [*Ногманның*] *колаклы бүрек астыннан кечкенә генә булып күренгән бите буенча борчак-борчак булып тир ага.* Р. Ильяс.

2. Зур колаклы кайбер хайваннар атамасы составында беренче сүз. *Колаклы ябалак. Колаклы майлык.*

КОЛАКСА *и.* **1.** Көймәдә ишкәк беркетә торган җайланма; *русчасы:* уключина. *Ишкәкләр --- колаксаларыннан салдырылмаган килеш кенә көймә эченә төшерелгән иде.* Ш. Маннур.

2. Чабатаның ян якларында киндерәне чалып тагып алу өчен ясалган тишек. [*Чабатаның*] *кырый юкәләрен тигез генә бора бару, колаксаларын таманча гына кую — шактый кыен эш.* Каз. утл.

3. Ниргәнеп, бәбкә утырту өчен, баш-башлары озынаеп чыгып торган иң өске аркылы бүрәнәсе.

КОЛАКСЫЗ *с. сөйл.* Саңгырау, чукрак.

◇ **Колаксыз калу** — саңгыраулану, чукраклану.

КОЛАКТАН-КОЛАККА *рәв.* **1.** Яшерен рәвештә. *Колактан-колакка төрле хәбәр йөри башлады.* И. Гази.

2. Башкаларга ишеттермичә. — *Сезнең анда бездән яшерен нинди серегез бар? Ник колактан-колакка сөйләшәсез?* М. Шабай.

КОЛАКЧА *и.* **1.** *к.* колакчын. *Карт, ишектән керү белән, бүрегенең колакчасына зур иске бияләен тидерде һәм [исәнләште].* Ш. Камал.

2. *диал.* Колак алкасы. *Колагыма таккан колакча, Йөрсәм талпынадыр бер якка.* Җыр.

3. *сөйл.* Күзлек сабы. *Озын Фәсәх, --- сыңар колакчалы күзлеген кия-кия, трибуна янына килде.* М. Хәсәнов.

КОЛАКЧАЛЫ *с. диал. к.* колакчынлы. [*Кичкырын безгә*] *башына кызыл йолдызлы колакчалы бүрек, өстенә шинель кигән --- берәү килде керде.* Г. Толымбай.

КОЛАКЧЫК *и.* **1.** Кечкенә колак (2—5 мәгъ.).

2. *анат.* Йөрәкнең венадан кан кабул итә торган югары өлеше. *Йөрәкнең уң һәм сул колакчыклары.*

КОЛАКЧЫН *и.* **1.** Бүрекнең колакларны каплап асылынып төшкән өлеше. [*Эшчеләрнең*] *барысының да бүрек колакчыннары куян колагы кебек тырпаеп тора.* Г. Ахунов. || *с. мәгъ. сөйл.* Шундый өлгедә тегелгән; колакчынлы. *Башына күн түбәле колакчын бүрек кигән --- авыл советы председателе Сөләйманов күренде.* Ә. Еники.

2. *сөйл.* Колакчынлы бүрек. *Яңа колакчын булды дип, искесен утка якма.* Мәкаль. [*Бикташ бабай*] *башына кыршылып беткән колакчынын батырды.* Г. Минский.

3. *махс.* Колакларга куеп тыңлау өчен дуга сыман металл пластинка белән тоташтырылган ике тавыш тыңлау аппаратыннан гыйбарәт прибор. *Телефон колакчыны.* □ *Үзем шигырь язам, радио колакчыны колагымда.* М. Җәлил.

КОЛАКЧЫНЛЫ *ф. сөйл.* Колакчын ясап тегелгән, колакчыны булган. [*Нурулла*], *җәен-кышын колакчынлы бүрек, сырган бишмәт киеп, өй арасында гына урала башлады.* А. Гыйләҗев.

КОЛАН *и. иск.* Матур, йөгерек кыргый ат. *Атасы болан атмаганның баласы колан атмас.* Мәкаль. *Монголларның иң яраткан аучылыгы коланга йөрү булып, аларны көтүе-көтүе белән кырганнар.* Н. Исәнбәт.

КОЛАЧ *и.* **1.** Ян якка сузылган ике кул арасы (бер кулның бармак очларыннан икенче кулның бармак очларына кадәр); шул аралыкка тигез озынлык үлчәү берәмлеге. *Мөгез аралары берәр колачка сузылган дәү үгезләр йокымсырап кына атлыйлар.* Г. Бәширов. — *Кызың алай бик зирәк булса, менә шушы бер саплам җептән биш колач киндер сугып бирсен.* И. Гази. *Ике кулың бер колач.* Әйтем. || Бер кулның бармак очларыннан икенче кулның бармак очларына кадәр әйләнә буенча булган озынлык; кочак. *Колач җитмәслек юан, кызыл иренле хатын бигрәк тә кызды.* Г. Мөхәммәтшин. *Тимерченең тимер йөрәге, --- Колачка чак сыяр күкрәге.* Ф. Кәрим.

2. *күч.* Нинди дә булса эшнең, эшчәнлекнең зурлыгы, күләме турында. *Бездә зур күләмле әсәрләр күп языла башлады, прозаның колачы чагыштыргысыз көчәйде.* Р. Мостафин. [*Рәхим*] *эшне бөтен колачы белән җәяргә исәпли иде.* А. Расих. *Бу җыр борынгырак инде, Безнең колач өчен кечкенә.* Ш. Маннур. || Эшчәнлек сәләте. [*Уйлап табучылар*] *арасында иң нык куандырганы Иштуган Уразметов булды. „Колачы киң егетнең“, дип уйлады Гаязов.* Г. Әпсәләмов. || Мөмкинлек. *Иҗат өчен колач киң бездә.* Г. Хуҗиев.

◇ **Колач салу** — кулларны су өстенә чыгарып алмаш-тилмәш алга күчерү; колачлау (йөзгән вакытта). *Һавага караганда җылырак булган суның чисталыгына, йомшаклыгына сокланып туя алмыйча, аргы як ярдагы бөдрә талларга карап, колач сала башладык.* М. Әмир. **Колач җәеп** — 1) бик теләп, шатланып. *Газинур аны колачын җәеп, сөенеп каршы алды.* Г. Әпсәләмов; 2) тулы көчкә, иркенләп. *Милли частька --- элэксәм, колач җәеп эшләргә булыр иде.* М. Җәлил. *Язучы дигән хөрмәтле исемгә лаек булган һәр кеше заман сулышын тоеп, колачын киң җәеп изҗат итәргә омтыла.* Г. Бакир. **Колач җәю** — күпләргә таралу, күпләрне җәлеп итү. *Культура революцияcе бездә --- киң колач җәйде.* Г. Бәширов. **Колачны киң җәю** — нинди дә булса эшне зур күләмдә алып бару, башкару яки шуңа омтылу. [*Әсәрнең төп кимчелеге*] — *колачны киң җәюдә, бер проблема өстендә ныклап эшләп, аны җанлы сурәтләр --- аркылы чишәргә теләмәүдә.* М. Җәлил.

КОЛАЧЛАУ *ф.* 1. Колач эченә алу. *Башына карасаң, бүрегең төшәрлек озын үскәннәр [агачлар]. Ике кеше колачлый алмаслык юанайганнар.* А. Таһиров.

2. Колач (1 мәгъ.) белән үлчәү. || *рәв. мәгъ.* **колачлап.** Колач озынлыгы белән. *Колачлап үлчәү.*

3. Кулларны су өстеннән алмаш-тилмәш алга күчереп (кроль стиле белән) йөзү, колач салып йөзү. *Синдбад диңгезгә ташлана, берничә колачлауга, корабка барып та җитә.* Мең дә бер кичә. || *рәв. мәгъ.* **колачлап.** Колач салып. *Петя, бик матур итеп колачлап йөзеп, эчкә үк кереп китте.* М. Гали.

4. *күч.* Үз карамагына, үз эшчәнлеге тирәсенә туплау, үз йогынтысы астына алу; тарту, җәлеп итү. *Фашизмга каршы көрәш миллионнарча кешеләрне колачлау.* || Тулысынча иңләү, үз эченә алу. *Гадәттә мондый вакыйганы үзләштерү, колачлау өчен язучыга еллар белән исәпләнгән күпмедер вакыт кирәк була.* Ә. Еники. *Татар халык иҗатының барлык жанрларын колачлаган теоретик хезмәтнең юклыгы үзен күптән сиздерә иде.* М. Мәһдиев.

◇ **Колачлап йөзү** — иркенләп, теләгәнчә эшләү, нәтиҗәле эш күрсәтү турында. *Миңа бит шушы Бикмуллаларга кушылырга да эштә колачлап йөзәргә генә кирәк иде, юк, кулдан килми.* М. Галәү.

КОЛАЧА *с.* Аксыл җирән, кола төстәге. [*Аның*] *өстендә колача кызыл җилән.* Ф. Кәрим.

КОЛАЧЛЫ *с.* 1. Зур, иркен, чикләнмәгән. *Партиянең XXIII съездында билгеләнгән чаралар совет кешесенә --- үзенең кемлеген күрсәтү өчен тагын да колачлырак мөмкинлекләр ача.* Ш. Хамматов.

2. Күп мәсьәләләрне эченә алган, тирән эчтәлекле (сәнгать әсәрләре, фәнни хезмәтләр турында). [*„Саф күңел“*] *әсәре — сугыш еллары турында колачлы романнарыбызның әйбәте.* А. Расих. *Автор нибары бер җөмлә белән нинди зур, колачлы картина тудыра алган.* Г. Ахунов.

3. Киң белемле, сәләтле. *Тәҗрибәле һәм колачлы шагыйрь.*

КОЛАЧЛЫЛЫК *и.* Колачлы булу сыйфаты. *Мин кайчакта Горькийдагы, Фадеевтагы колачлылыкны, милли әдәбиятларның эченә үтеп кергән сизгер, киң карашны сагынам.* С. Хәким.

КОЛАША *и.* Кәбестә турау, орлык киптерү һ. б. өчен агачтан эшләнгән тагарак. [*Гали*], *колаша белән кәләвә күтәреп, базарга юнәлә.* Н. Исәнбәт. — *Мин колаша белән мунчага салат күтәргән идем, кипмәдеме икән?* Әкият. || Шундый формада эшләнгән яки шуны хәтерләткән һәртөрле әйбер, җайланма. *Латыйплар килене самоварын соскыга каккан да көлен, уты-нце белән, лапастагы кабык колащага түккән.* А. Гыйләҗев. [*Чишмәне*] *чистартырга, яңа колаша куярга кирәк.* Г. Мөхәммәтшин.

КОЛАШАЛАНДЫРУ *ф.* Колаша формасына китерү. [*Әлбидә*] *каяндыр ылыс астыннан --- пыяла банка тартып алды да төргән билетларны колашаландырыбрак шуның эченә төшерде.* Ш. Маннур.

КОЛАШАЛАНУ *ф.* Колаша рәвешенә килү.

КОЛАШАЛЫ *с.* Колаша формасындагы. [*Тансык*] *авыл буйлап кешеләрнең җилкә өстендә колашалы кабыкта баручы май әбисенә --- моңаеп карый.* Г. Ахунов.

КО'ЛБА *и.* Химик эшләр өчен кулланыла торган озын муенлы пыяла савыт. *Фабриканың химия лабораториясе. --- Разия колбалар янында эшли.* Р. Ишморат. *Әбүгалисина --- аркасындагы төенчеген салган, аннан китап, бер-ике пыяла колба --- чыгарып куйган.* Н. Исәнбәт.

КОЛБАСА *и.* Эчәккә яки ясалма яры тышчага тутырып махсус хәзерләнгән ит фаршы — ашамлык әйбере; казылык. *Өстәлгә биш йолдызлы бер шешә, рюмкалар, сыр, колбаса куелды.* Г. Минский. *Лейтенант Дугаров --- колбаса һәм ипи кисәкләрен [кунакның] алдынарак этеп куйды.* А. Шамов.

КОЛБИЛӘҮЧЕ *и.* Колбиләүчелек җәмгыятендә өстен сыйныф вәкиле, колның (колларның) хуҗасы *Колларның колбиләүчеләргә каршы көрәше.*

КОЛБИЛӘҮЧЕЛЕК *с.* Коллыкка, коллар хезмәтенә нигезләнгән. *Колбиләүчелек дәүләте. Колбиләүчелек хуҗалыгы.*

Колбиләүчелек строе (җәмгыяте) — кешенең кешене эксплуатацияләвенә нигезләнгән беренче антагонистик иҗтимагый-экономик формация. *Колбиләүчелек җәмгыятенең таркалуы.*

КОЛГА *и.* 1. Озын, юан (гадәттә вертикаль утыртып куелган) киртә, багана. *Биек колга башындагы кечкенә оялары каршысында борыла-борыла сыерчыклар сайрый.* Г. Бәширов. || Сыгылмалы озын таяк формасындагы спорт снаряды. *Колга белән сикерү.* □ [*Залга*] *физкультура җиһазлары тутырдылар: төрле герләр, озын баскычлар, колгалар, магын әллә нәрсәләр.* Г. Гобәй.

2. *күч. гади. с.* Озын буйлы, озын аяклы, колгасар кеше турында. [*Неплюйко, озын аяклы немец солдатына күрсәтеп:*] *Рөхсәт итегез, хәзер мин ул колганы бер пуля белән...* И. Гази.

Колгага менү — сабан туенда спорт уеннарының бер төре: озын шома багананың очына кадәр куллар һәм аяклар ярдәмендә күтәрелү.

КОЛГАЛЫ *с.* Колгага (озын таякка) беркетелгән, сапланган. *Колгалы бакча кайчысы. Колгалы алма җыйгыч.*

КОЛГАСАР *с.* Бик озын буйлы (кеше турында). *Теге колгасар матрос --- кешеләрне аралый-ера һаман алга узмакчы булды.* С. Сабиров.

КОЛЕНКО'Р *и.* Ак яки нинди дә булса башка бер төстәге ник ашланган киҗе-мамык тукыманың бер төре. *Коленкор белән төпләнгән китап.* || *с. мәгъ.* Коленкордан тегелгән, эшләнгән. *Коленкор тышлык. Коленкор күлмәк.*

КОЛЕСНИ'ЦА *и. тар.* Борынгы греклар һәм римлылар сугышта һәм ярышларда кулланган ике тәгәрмәчле җиңел арба. — *Бүген цирктa моңарчы булмаган зур тамаша: Капуй мәктәбеннән биш йөз гладиатор сугышачак, --- колесницалар сугышы булачак.* Н. Исәнбәт.

КОЛЕЯ *и.* Параллель салынган ике рельслы тимер юл. *Тимер юл колеясы. Тар колеялы юл. Киң колеялы юл.*

КОЛИ'БРИ *и. зоол.* Ачык төстәге матур каурыйлы бик кечкенә кош (Америкада яши). [*Орхидеяләр*]

кечкенә генә кошлар — колибрилар ярдәмендә дә серкәләнәләр. Робинзон әзл.

КОЛИТ *и. мед.* Юан эчәкнең ялкынсыну. *Яшерен формадагы малярия һәм колит белән авырыйм.* Г. Ибраһимов.

КОЛЛАБОРАЦИОНИЗМ *и. полит.* Икенче бөтендөнья сугышы чорында үз илләрен басып алган фашистлар белән хыянәтчел хезмәттәшлек.

КОЛЛАБОРАЦИОНИСТ *и. полит.* Коллаборационизм тарафдары, икенче бөтендөнья сугышы чорында үз илләрен басып алган фашистлар белән хезмәттәшлек иткән сатлык җан, хыянәтче кеше. *Каршылык хәрәкәте членнарының һәркайсының кечкенә генә эше булган. Тиммерманска исә коллаборационистларның исемлеген төзү тапшырылган.* Сов. әд.

КОЛЛАБОРАЦИОНИСТЛЫК *и. к.* коллаборационизм.

КОЛЛАНУ *ф. сир.* Колларча баш ию, буйсыну.

КОЛЛА'РЧА *рәв.* Кол(лар) кебек, колларга хас рәвештә. *Колларча яшәү. Колларча буйсыну.* □ *Абыстай, бу колларча ихтыярсыз һәм буйсынучан хатынның аш-суга осталыгын да күргәч, аны аш өендә генә эшләргә калдырды.* Г. Минский.

КОЛЛАУЧЫ *и. иск.* Кол кызлар белән сату-алу итүче. *Коллаучыга кыз ошатып булмас.* Мәкаль.

КОЛЛЕ'ГА *и.* Эш, профессия һ. б. буенча иптәш; хезмәттәш. — *Без аның белән бер коллектив членнары, коллегалар.* Р. Ишморат. [*Зөбәрҗәт*] *иртәдән кичкә хәтле клиникадагы коллегалары янында булды.* А. Расих.

КОЛЛЕ'ГАЛЫК *и.* Коллегалар булу хәле.

КОЛЛЕГИАЛЬ *с.* Сайланып куелган бер төркем кешеләр тарафыннан бергәләп алып барыла торган. *Коллегиаль җитәкчелек. Мәсьәләне коллегиаль рәвештә хәл итү.*

КОЛЛЕГИАЛЬЛЕК *и.* Бер төркем кешеләр тарафыннан тормышка ашырыла торган коллегиаль җитәкчелек, идарә итү. *Коллегиальлек принцибы.*

КОЛЛЕ'ГИЯ *и.* **1.** Киңәшү яки карар чыгару органы буларак рәсми билгеләнгән берничә кешелек группа. *Чит ил эшләре коллегиясе. Режиссерлар коллегиясе.* □ [*Губземотдел*] *мәсьәләне коллегиядә караган чагында гаризада язылганнарны --- исәпкә алырга вәгъдә биргән.* Ш. Камал.

2. Кайбер профессия кешеләре берләшмәсе. [*Гаепләнүче*] *дхми белән Гыймадины яклаучылар коллегиясе әгъзаларыннан бер яшь юрист алган икән.* Г. Ибраһимов.

3. Россиядә XVIII йөздә үзәк хөкүмәт учреждениеләре исеме. *Хәрби коллегия. Тышкы эшләр коллегиясе.*

4. *иск.* Көнбатыш Европада һәм революциягә кадәрге Россиядә кайбер ябык урта һәм кайбер югары уку йортларының исеме.

КОЛЛЕДЖ *и.* Англиядә һәм Америкада югары яки урта уку йорты. *Кичен безне студентлар колледж һәм мәктәп укучыларының үзешчән сәнгать концертына чакырдылар.* М. Мәхмүтов.

КОЛЛЕЖ *и.* Франциядә, Бельгиядә һәм Швейцариядә урта уку йорты.

КОЛЛЕКТИВ *и.* **1.** Уртак максатлар, уртак эшчәнлек нигезендә берләшкән кешеләр төркеме. *Үзешчән сәнгать коллективы.* □ *Безнең халык—оешкан һәм бердәм бөек коллектив.* М. Җәлил. || Бер оешма, учреждение, предприятие составында даими рәвештә эшләгән кешеләр берләшмәсе. *Укытучылар коллективы. Завод коллективы.* □ *Эрләүче кыз Рабига коллективында алдынгы икән, дхмәтнең дә үз коллективында алдынгы булырга хакы юкмыни?!* Г. Минский.

2. *с. мәгъ.* Гомуми, уртак; күмәк көч белән башкарыла торган. *Коллектив хезмәт. Коллектив хуҗалык. Коллектив йөкләмә.* □ *Коллектив көч җиңде.* Г. Гобәй. || Коллективка хезмәт итә торган, коллектив файдасы өчен яши торган. *Газета — коллектив пропагандист һәм коллектив агитатор гына түгел, шулай ук коллектив оештыручы да.* В. И. Ленин.

Коллектив договор — предприятиенең администрациясе белән профсоюз оешмасы арасында эш шартлары турында төзелә торган килешү. *Коллектив договорның үтәлешен тикшерү.*

КОЛЛЕКТИВИЗМ *и.* Хезмәт ияләре арасында шәхси интересларны иҗтимагый интересларга буйсындыруга нигезләнгән иптәшләрчә хезмәттәшлек, үзара ярдәмләшүчелек. — *Без чын коллективизм турында, зур дуслык турында зур сөйләшү үткәрергә тиешбез.* Г. Әпсәләмов.

КОЛЛЕКТИВЛАШТЫРУ *ф. к.* колхозлаштыру. *Авыл хуҗалыгын коллективлаштыру.*

КОЛЛЕКТИВЛАШУ *ф. к.* колхозлашу. *Коллективлашу кызу барган, кулак калдыкларының каршылыгы бик кискенләшкән чаклар иде бу чор.* Каз. утл.

КОЛЛЕКТИВЛЫК *и. к.* коллективчылык. *Җитәкчелектә коллективлык принципларына таяну.* || *с. мәгъ.* Коллективка бәйләнешле, коллективчыл. *Эшчеләр арасында коллективлык хисләре тәрбияләү.*

КОЛЛЕКТИВЧЫ *и.* Коллективизм тарафдары.

КОЛЛЕКТИВЧЫЛ *с.* **1.** Коллективны яратучан, коллективка тиз ияләшүчән.

2. Коллективчыга хас.

КОЛЛЕКТИВЧЫЛЫК *и.* Күмәклек, бердәмлек, коллективизм. *Коллективчылыкка омтылу.* || *с. мәгъ.* Коллективизмга нигезләнгән. [*Җыентыкка кергән*] *бу җырларның барысыннан да --- бердәмлек, коллективчылык тойгылары кызыл җеп булып сузылалар.* М. Җәлил.

КОЛЛЕ'КТОР *и. махс.* **1.** Нәрсәне дә булса җыю һәм бүлеп тарату белән шөгыльләнүче учреждение. *Китапханә коллекторы.*

2. Нинди дә булса үрнәкләрне (мәсәлән, тау токымнарын, туфрак үрнәкләрен) җыеп, язып бара һәм саклый торган кеше. [*Миләүшәне*] *җир катламнарын картага төшерүче партиягә коллектор итеп алдылар.* М. Әмир.

3. *тех.* Динамомашинаның алмаш токны даими токка әйләндерә торган кисәге.

4. *тех.* Төрле трубалардан һәм каналлардан килгән сыекчаларны, газларны җыеп, кая да булса җибәрү өчен зуррак канал яки труба. *Канализация коллекторы.* □ *Утны туктату өчен газ килү каналын— коллекторны ябарга кирәк.* Г. Ахунов.

КОЛЛЕКЦИОНЕР *и.* Коллекцияләр җыючы. *Минем күп төрле коллекционерларны кургәнем бар: берәүләр марка җыя, шырпы кабы, акча.* Каз. утл.

КОЛЛЕ'КЦИЯ *и.* Бер төрдәге әйберләрнең билгеле бер системада тупланган җыелмасы. *Үсемлекләр коллекциясе.* □ [*Рәшит:*] *Кара, Гөлзадә, мин үземнең коллекциямә нинди кыйммәтле экспонатлар таптым.* Р. Ишморат. *Кайберәүләр ташлар, күбәләкләр җыя, икенче берәүләр маркалар коллекциясе төзи.* Г. Кутуй.

КОЛЛЕ'КЦИЯЛӘШТЕРҮ *ф.* Коллекция төзү, коллекция итеп җыеп бару, җыеп кую.

КОЛЛЕ'КЦИЯЛӘҮ *ф.* Коллекция итеп җыю. *Иске акчаларны коллекцияләү. Почта маркаларын коллекцияләү.*

КОЛЛИ'ЗИЯ *и.* Капма-каршы карашларның, көчләрнең, интересларның бәрелеше. *Ш. Камал әсәрләрендә яратып бирелгән коллизияләрнең берсе — хыял*

белән хакыйкатьнең бәрелеше. Г. Нигъмәти. *Тормыш коллизияләре без уйлаганнан күбрәк һәм катлаулырак.* Каз. утл. || Матур әдәбиятта тормыш конфликтларын һәм көрәшне сурәтләү, күрсәтү. *Такташ --- әсәрдә алынган вакыйгаларга романтик рух өрә, аларга мәһабәт рәвеш бирә, аларны коллизияләр дәрәҗәсенә күтәрә.* Х. Госман.

КОЛЛО'ДИЙ, КОЛЛО'ДИУМ *и. хим.* Үсемлек күзәнәкләренең тышчасында була торган матдәдән спирт һәм эфир катнаштырып ясалган куе, ябышучан эремә (медицинада һәм фотографиядә кулланыла).

КОЛЛО'ИД *и. хим.* Кристаллашмый һәм эремәләре хайван тиресе, үсемлек элпәләре аша үтеп чыга алмый торган матдә (крахмал, аксым, җилем һ. б. ш.).

Коллоид эремә — сыеклыкта бик вак, ләкин молекулалардан эрерәк кисәкчекләрдән торган йөзмә. **Коллоидлар химиясе** — физик химиянең коллоидлар үзлеген тикшерә торган бүлеге.

КОЛЛО'ИДЛЫ *с. хим.* Коллоиды булган; коллоид барлыкка китерә торган. *Коллоидлы матдәләр. Коллоидлы процесслар.*

КОЛЛО'ИДЛЫК *и. хим.* Коллоидлы булу сыйфаты, үзлеге. *Балчык измәсенең коллоидлыгы югары булу.*

КОЛЛО'КВИУМ *и. кит.* Студентларның белемнәрен сынау һәм күтәрү максаты белән укытучы тарафыннан үткәрелә торган әңгәмә. — [*Латин теленнән*] *коллоквиум уздырырбыз, ансыз ярамый.* Э. Касыймов.

КОЛЛЫК *и.* **1.** Кол булу хәле. *Яшәсен капитализм коллыгыннан азатлыкка алып бара торган көрәш!* М. Гафури. *Без яшибез коллык һәм изелүгә Чик куелган Совет иләндә.* М. Җәлил. *Без коллык, наданлык дошманы.* К. Тинчурин. || *с. мәгъ.* Кол булу хәленә бәйләнешле. *Коллык психологиясе.* □ *Син бәек, син көчле милләт — Атла коллык киртәсен.* Н. Думави. *Кинәт Идмас шундый мескен, шундый кызганыч булып калды: күзләрендә --- курку, коллык үтенүе күренде.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Коллар көченнән файдалануга нигезләнгән. *Борынгы коллык җәмгыяте.*

◇ **Коллык итү (кылу)** — 1) колларча хезмәт итү, эшләү. *Коллык иткән бәеклек табар.* Мәкаль; 2) нәрсәгә дә булса табыну, үз иркеңне, эшләгән эшләреңне тулысынча шуңа буйсындыру. [*Буржуй:*] *Акчага коллык кылулар сеңгән инде каныма.* Г. Камал; 3) *иск.* бил бөгеп, түбәнчелек күрсәтү (исәнләшкәндә). *Бакый, Шаһтимерне күреп, коллык итә: — Хуш килдең, мирза!* М. Фәйзи. **Коллыкка төшерү** — кол итү; буйсындыру, бәйле, буйсынулы хәлгә кую. *Совет халкын коллыкка төшерергә омтылучы кыргый фашистларга каршы Мансуров күңелендә берничек тә басылмаслык нәфрәт --- туды.* Г. Бәширов. **Коллыкка чакыру** *дини.* — алла каршында тез чүгәргә, намаз укырга чакыру. *Мәзин, манарадан азан кычкырып, мөселманнарны йокыларыннан уята, коллыкка чакыра башлады.* Ш. Камал.

КОЛМАК *и.* Тут агачлары семьялыгыннан үрмәле үсемлек, кайбер культуралы төрләре сыра ясау өчен файдаланыла. *Тал чыбыкка һәм шомыртка Яшел колмак уралган.* Ә. Ерикәй. *Куаклыклар күптән шәрәләнгән. --- Сары колмак сабакларына кадәр аермачык күренеп торалар.* М. Хәсәнов. || *җый.* Шул үсемлекнең нарат күркәсе сыман оешма чәчәге. [*Трактирчы:*] *Колмак салып, сарымсак салып ясалган сыра --- бар.* М. Гали.

КОЛМАКЛЫ *с.* Колмак кушылган (ачыту яки тәм бирү өчен).

КОЛМАКЛЫК *и.* Колмак (күп) үсә торган урын, әрәмәлек.

КОЛМАКЧЫ *и.* Колмак үстерү хуҗалыгында эшләүче; колмак үстерү белгече.

КОЛМАКЧЫЛЫК *и.* Авыл хуҗалыгының колмак үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы.

КОЛОВОРОТ *и.* Гадәттә агач әйберләрне кул белән бораулап тишү өчен отвёртка, борау кебек нәрсәләрне беркетеп әйләндерә торган терсәкле вал формасындагы эш коралы; боргычлы борау.

КОЛО'ДА *и. махс.* Уен карталарының тулы комплекты. [*Закир*], *өстәлдә ята торган карта колодасын алып, хәзрәт каршысына килде.* Ф. Әмирхан.

КОЛО'ДКА *и.* **1.** Тормоз шкивы яки тәгәрмәч тугымы янына хәрәкәтне тоткарлау яки булдырмау өчен кыстырылып куела торган, билгеле бер калыпта махсус эшләнгән агач яки тимер башмак. *Тәгәрмәчләр алдында махсус эшләнгән тормоз колодкалары куелмаган булса, самолётыбыз очып ук китәчәк иде.* С. Баттал. || Ике аяксыз кешенең куллары белән таянып хәрәкәт итүе өчен җайланган агач шакмак. *Каяндыр, туп кебек тәгәрәп, бер кеше яртысы килеп чыкты. --- Таза кулларында күченеп йөрү өчен махсус агач колодкалар иде.* Г. Минский.

2. Элекке заманда, качып китмәсен өчен, тоткынларның, кулга алынган кешеләрнең аякларына, кулларына яки муеннарына кидерә торган зур агач богау. *Зур капканы ачып, --- тимер богаулар һәм агач колодкалар төялгән йөкле атларны* [*керттеләр*]. М. Гали. *Картның муенына агач колодка киерткәннәр.* Г. Әпсәләмов.

3. Күкрәккә орденнар, медальләр яки орден тасмалары тагып йөртү өчен махсус эшләнгән планка. [*Симаков*] *күкрәгенә барлык орден колодкаларын тагып йөрде.* Ә. Еники. *Офицер кительләрен орден һәм медаль колодкалары белән бизәгән --- „шәкертләр“ шактый иде университетта.* М. Хәсәнов.

Колодкага утырту — аякка колодка кидерү. — *Толокнов Семен белән Бабин Иванны колодкага утырттылар! — дип кычкырды --- берсе.* М. Гали.

КО'ЛОКОЛ *и. сөйл.* **1.** *к.* чаң I (1 мәгъ.). *Хәзер монда пасхада чиркәү колоколы тавышыннан туйдык инде.* Ш. Мөхәммәдев. *Вокзал колоколының икене бәргән тавышы зыңлап яңгырады.* Г. Минский.

2. *к.* кыңгырау 1. *Сафыйлар капкасыннан, яхшы тарантаска пар ат җигеп, колокол шалтыратып, өч егет чыгып киттеләр.* Г. Гали.

КОЛОН *и. тар.* **1.** Борынгы Римда: эре җир биләүчедән арендага зур булмаган җир участогы алган кеше. *Колоннар хезмәт белән коллардан ныграк кызыксынганнар, чөнки аларның үз хуҗалыклары булган.* Политэкономия.

2. Роман һәм Латин Америкасы илләрендә төрле катлау крестьяннарның (батракларның, уртакка, өлешкә эшләүчеләрнең, ярым крепостной арендаторларның) атамасы.

КОЛОНАТ *и. тар.* Рим империясе һәм башлангыч урта гасырлар чорында авыл халкының эре җир биләүчеләргә бәйлелек формасы (феодаль мөнәсәбәтләрнең тууына нигез булып хезмәт иткән). *Феодализм элементлары, колонат рәвешендә, колбиләүчелек җәмгыяте эчендә үк туган.* Политэкономия.

КОЛОНИАЛИЗМ *и. полит.* Экономик көчсезрәк булган илләрне империалистик державаларга тулы экономик һәм политик бәйле итү, колонияга әйләндерү политикасы. *Колониализм мирасын бетерү.* □ *Хәзерге колониализмның төп төрәге — Америка Кушма Штатлары империализмы.* КПСС Программасы.

КОЛОНИАЛЬ *с.* **1.** Колониягә әйләндерелгән, колония (1 мәгъ.) хәленә төшерелгән. *Колониаль биләмәләр. Колониаль илләр.* □ *Ярым колониаль шартларда изелеп яшәгән бик күп халыкларга революция үз культураларын үстерергә киң мөмкинлек ачты.* Г. Бәширов. || Колонияләрдә яшәүче. *Инде бөтен коло-*

ниаль халыклар коллык богауларына каршы көрәшкә күтәрелде. Р. Төхфәтуллин.

2. Колонияләр (1 мәгъ.) биләүгә бәйләнгән. *Колониаль мәсьәлә.* □ *Бу романда революциягә кадәрге Казахстан тормышы картиналары, аның ыруг һәм социаль көрәшләре һәм патша самодержавиесенең колониаль политикасы бирелгән.* Г. Ибраһимов. || Колонияләр биләүче. *Колониаль державалар.*

Колониаль сугышлар — империалистик дәүләтләр тарафыннан колонияләр яулап алу яки колонияләрдәге хакимлекне саклап калу өчен алып барыла торган сугышлар.

КОЛОНИЗА'ТОР *и.* 1. Колонияләрдәге (1 мәгъ.) хезмәт ияләре массасын буйсындырып яшәтүче, эксплуатацияләүче. *Инглиз колонизаторлары [Колчакны] Месопотамия фронтына җибәрмәкче булалар.* И. Гази. *Бу шәһәр чиновниклар, сәүдәгәрләр, спекулянтлар, колонизаторлар белән тулган иде.* Ш. Усманов.

2. Буш, кеше яшәми торган урыннарга күчеп утыручы; колонист.

КОЛОНИЗА'ТОРЛЫК *с.* Колонияләр басып алуга юнәлтелгән. *Царизмның колонизаторлык политикасы милли телләрнең үсешенә тоткарлык ясады.* Соц. Тат.

КОЛОНИЗА'ЦИЯ *и.* 1. Чит илне басып алу һәм аны колониягә (1 мәгъ.) әйләндерү эше, политикасы. *Негрлар Латин Америкасына, европалыларның шикәр камышы, тәмәке, мамык плантацияләрендә кол итеп эшләтү өчен, колонизация чорында Африкадан көчләп китерелгәннәр.* Чит ил. экон. геогр.

2. Буш яткан урыннарга халык (колонистлар) күчерү, урнаштыру эше.

КОЛОНИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Чит илне басып алу һәм аны көчләп колониягә (1 мәгъ.) әйләндерү. *Африка илләрен колонизацияләү.*

2. Буш яткан урыннарга халык (колонистлар) күчерү, урнаштыру. *1552 елда элекке Болгар-Казан җирләре руслар тарафыннан колонизацияләнә башлый.* Каз. утл.

КОЛОНИСТ *и.* Колониядә (2, 4 мәгъ.) торучы кеше. *[Чегән малае колониядә дә] канына сеңгән кәсебен ташламады. --- Һич югында үзенекен урлый иде. Клубтамы, мәктәптәме, ашханәдәме үзенең карандашын, кашыгын --- берәр колонистның кесәсенә шудыра да, бөтенесе өерелеп ишектән чыккан чакта урлый.* Г. Гобәй.

КОЛО'НИЯ *и.* 1. Империалистик дәүләт тарафыннан көчләп басып алынган һәм эксплуатацияләнә торган ил. *Испаниялеләр Американы колония итеп торганда, 40 ел эчендә, 15 миллион индиялеләрне бөтенләй бетерделәр.* Урал. *[М. Гафури бу шигырендә] Европа империализмы тарафыннан таланучы көнчыгыш колония халыкларының хәлләрен сурәтли.* М. Җәлил.

2. Икенче дәүләттән, өлкәдән күчеп килгән кешеләр яши торган урын (авыл, шәһәрчек, квартал). *Кара диңгез ярларында күп кенә грек колонияләре төзелгән.* Бор. зам. тарихы. *Болгар дәүләтенең шәһәрләрендә хәтта кечкенә рус колонияләре дә була.* Каз. утл.

3. Нинди дә булса чит шәһәрдә, чит дәүләттә яши торган якташларның берләшмәсе. *[Сөргендә], социал-демократлар колониясендә, карт революционер бар иде.* Г. Ибраһимов.

4. Теге яки бу максат белән (дәвалау, тәрбияләү, җәзасын үтәрү һ. б. өчен) берәр җиргә җибәрелгән кешеләрнең торак урыны. *Чукрак-телсезләр колониясе. Хезмәт-төзәтү колониясе.* □ *Җиһангир, бик тиз кулга алынып, яшь җинаятьчеләр колониясенә озатылды.* Г. Гобәй.

5. *и. биол.* Бергә тоташып, укмашып үсә, күпләп бер тирәгә җыйналып яши торган үсемлек яки жанварлар төркеме. *Кырмыскалар колониясе. Мәрҗәннәр колониясе.* □ *Болан уты урманда колония булып үсә.* Н. Исәнбәт. *Яз көне Врангель атавына бик күп ак казлар очып килә. Алар һәркайсында 500 парга кадәр каз булган колонияләр булып урнашалар.* Соц. Тат.

КОЛО'НИЯЛЕ *с.* Колониясе яки колонияләре булган. *Икенче бөтендөнья сугышында колонияле империяләрнең җимерелүе.*

КОЛО'НИЯЛӘШТЕРҮ *ф. к.* колонизацияләү. *Колонияләштерү политикасы.*

КОЛО'НИЯЧЕ *и. к.* колонизатор. *Колонячеләрнең „Бүлгәләп хакимлек ит!" дигән кагыйдәсе буенча эш итүче немецлар „Олуг Төркстан" [дәүләте төзелүдән] өркеп калалар.* Ш. Маннур.

КОЛО'НИЯЧЕЛЕК *и.* 1. *к.* колонизация. *Көнчыгыш халыкларының колонячелеккә каршы күтәрелүләре.* || *с. мәгъ.* Колонияләр (1 мәгъ.) яулап алуга бәйләнешле. *Колонячелек политикасы үткәрү.*

2. *с.* Буш яткан урыннарга колонистлар урнаштыру, күчерүгә бәйләнешле.

КОЛО'НКА *и.* 1. Озынча цилиндр формасындагы төрле җайланмаларның (мәсәлән, ваннада су җылыта торган цилиндрик казанның, су яки бензин агызу өчен тоткалы һәм кранлы биек цилиндр формасындагы җайланманың) атамасы. *Бензин колонкасы.* □ *Мин капка төбендәге колонкадан әнигә су ташыдым.* Р. Төхфәтуллин.

КОЛО'ННА *и.* 1. Фронтоннарны, бинаның эчке өлешләрен терәп тотып торган архитектура корылмасының юан һәм озын багана сыман бер кисәге. *Зур театр колонналары.* □ *Колонналар белән бизәлгән ике катлы ак бинага кергәч, безнең якташлар йөзләгән кешеләр арасында югалып калдылар.* С. Рафиков. || Нинди дә булса зур вакыйга хөрмәтенә шундый формада эшләнгән һәйкәл, монумент. *Триумфаль колонна.*

2. Берсе артына икенчесе басып тезелгән хәрби хезмәткәрләр, хәрби отрядлар рәте, сафы (сафның озынлыгы аркылысыннан зуррак яки шуна тигез була). *Минем бабай бөек рус армиясенең беренче колоннасында Берлинны үткән, беренче колоннада Парижга бәреп кергән.* А. Шамов. || Шундый тәртиптә урнашкан яки хәрәкәт итә торган кешеләр һәм предметлар төркеме. *Байракчылар колоннасы.* □ *Комсомоллар Ирек мәйданына колонналар булып агылалар.* Һ. Такташ. *Танклар колоннасы көнбатышка таба юлга чыкканда, таң беленергә байтак бар иде әле.* М. Әмир.

3. Бер урыннан икенче урынга күчеп, гомуми производство заданиесен үти торган машиналар, тракторлар һ. б. ш. төркеме. *Автотранспорт хуҗалыгыннан прицеплары-ниләре белән тулы бер колонна машина сорауның да кирәге бетте.* М. Хәсәнов. *„Кан тавышы" хикәясендә сүз авылга трактор колоннасы --- килү турында бара* М. Җәлил.

КОЛО'ННАЛЫ *с.* Колонналар (1 мәгъ.) белән эшләнгән. *Колонналы зал.* □ *Дә тегә колонналы ак йорт госпиталь була.* Г. Әпсәләмов.

КОЛОННА'ДА *и.* Гомуми түшәмә астындагы колонналар (1 мәгъ.) рәте. *Бу сарай үзенең фронтонары һәм колоннадалары белән безнең Казан университеты фасадын хәтерләтә.* Г. Галиев.

КОЛОНТИ'ТУЛ *и. махс.* Битнең өстендә китап яки әсәрнең исемен, авторының фамилиясен кабатлап

күрсәтә торган, шул битнең эчтәлегенә ишарә итә торган язма.

КОЛОНЦИ'ФРА *и. махс.* Китап, журнал һ. б. ш. ларның битләрен номерлый торган цифр.

КОЛОРАД: колорад коңгызы — канат өсләре кабарынкы, тәне саргылт төстәге бәрәңге өчен иң куркынычлы корткыч бөҗәк.

КОЛОРАТУ'РА *и. муз.* 1. Вокаль партияне техник яктан кыен булган тавыш калтыратулар, сузулар, кискен үзгәртүләр белән бизәү.

2. Шундый вокаль партияне җиңел башкара алырлык тавыш сәләте.

КОЛОРАТУ'РАЛЫ *с.* Колоратурага ия булган. *Колоратуралы сопрано.*

КОЛОРИСТ *и.* 1. Буяулар белән оста эш итүче художник, колорит (1 мәгъ.) остасы.

2. Тукымалар буяучы белгеч.

КОЛОРИТ *и. кит.* 1. Сәнгать әсәрләрендә (мәсәлән, матур әдәбиятта, картинада, гравюрада, орнаментта һ. б.) буяуларның тон һәм төс тулылыгы ягыннан бер-берсенә мөнәсәбәтләре. *Әгәр язучы авыл турында яза икән, ул инде һич тә бер көлке карт образын тудырмый калмый, гүя ансыз дөнья сансыз, авылның колориты югала.* Каз. утл. || Нинди дә булса әйбергә тон бирүче буяулар, төсләр катнашмасының гомуми характеры.

2. Нәрсәнең дә булса үзенчәлекле, үзенә генә хас билгеләр җыелмасы. *Милли тел колориты.* □ *Күргәзмәдә булган һәр кеше Татарстан павильонын яхшы хәтерлидер. --- Биредә һәрнәрсә милли колорит белән сугарылган.* Каз. утл.

КОЛОРИТЛЫ *с. кит.* 1. Буяулар, төсләр катнашмасының төрлелеге белән аерылып торган (картина, гравюра һ. б. ш. турында). *Сүз әсәрнең эчтәлегенә карап язылган декорацияләр, махсус тегелгән костюмнар, колоритлы гримнар турында бара.* Ж. Фәйзи.

2. Үзенчәлекле, характерлы. *„Канатланыр чак"-ның төп герое Хәлим түгел, Кафия. Дсәрнең иң колоритлы, иң җанлы образы әнә шул.* Г. Ахунов. | *рәв. мәгъ. Хезмәттә түй йолалары җитәрлек дәрәҗәдә ачык һәм колоритлы күрсәтелгән.* Каз. утл.

КОЛОРИТЛЫЛЫК *и.* Колоритлы булу сыйфаты. *Казан татарлары ювелир сәнгате үзенең формалар байлыгы һәм колоритлылыгы белән аерылып тора.* Соц. Тат.

КОЛОРИТЧЫ *и. к.* колорист.

КОЛТ-КОЛТ *аваз иярт. к.* голт-голт. [*Галиулла*] *кызып-кызып эшли дә, флягасын күтәреп, колт-колт су йота.* И. Гази.

КОЛУН *и.* Утын яра торган калын йөзле авыр балта. — *Бәләкәй генә чебенгә каршы утын яра торган колун күтәрү төсле тоела бу* [*эш*] *миңа.* Ш. Камал.

КОЛХОЗ *и.* Авыл хуҗалыгы эшләрен бергәләшеп алып бару өчен хезмәт иясе крестьяннарның ирекле берләшүенә нигезләнгән социалистик күмәк хуҗалык. *Колхозга керү. Колхоз идарәсе. Колхоз фермасы.* □ *Ул авылда тырышып колхоз төзегән, Өлгергән ярлы-ялчыны.* Һ. Такташ. || *с. мәгъ.* Коллектив хуҗалык формасына нигезләнгән. *Колхоз төзелеше.* □ *Колхоз милке үзебезнең Ялгыз милкебездән кадерле!* Ә. Исхак. || Колхозда эшләүче кешеләр коллективы, колхозчылар. *Айсылу белән Нәфисәне бөтен колхоз белән зарыгып көтәләр иде.* Г. Бәширов.

КОЛХО'ЗАРА *с.* 1. Колхозлар арасында башкарыла торган, яшәп килгән. *Колхозара социалистик ярыш.*

2. Берничә колхоз өчен уртак булган. *Колхозара электр станциясе, Колхозара юл бүлеге.*

КОЛХОЗДАШ *и.* Кем белән дә булса бер үк колхоздан булган колхозчы. *Караңгы бараста колхоздашлар таң сызыла башлаганчы сөйләштеләр.* Г. Әпсәләмов.

КОЛХОЗЛАШТЫРУ *ф.* Вак крестьян хуҗалыкларын эре социалистик хуҗалыкларга — колхозларга берләштерү. *Колхозлаштыру елларында аны куштан Сәйфи дип тә йөрткәннәр.* Г. Бәширов.

КОЛХОЗЛАШУ *ф.* Эре социалистик хуҗалыкларга — колхозларга берләшү. — *Хәзер инде, агай, бер сезнең авылда гына түгел, бөтен Советлар Союзында колхозлашу бара.* С. Рафиков.

КОЛХОЗЧЫ *и.* Колхоз члены. *Колхозчылар җыелышы.* □ *Үләннәрдән әнҗе коя-коя, Колхозчылар чыга болынга.* З. Мансур.

КОЛЧЕДАН *и.* Тимер, никель, бакыр һ. б. металлар белән күкерт, шулай ук сөрмә, мышьяк кушылмалары катнашмасыннан торган минералларның гомуми атамасы. *Колчеданнар авыр, колчеданнар каты Тимердән дә, бакыр, таштан да; Д шулай да җимерү авыр түгел, Динамитлар салып атканда.* Ш. Маннур.

КОЛЫН *и.* Ат баласы (бер яшькә кадәр). *Колын үсеп, җиңел-җилпе ат эшенә ярый башлагач та, Ишмай аның әнкәсен, аз-маз симертеп, сугымлыкка сатты.* Ш. Камал.

Колын ташлау (салу) — атның вакытыннан алда, колыны җитлекмәс борын колынлавы турында (нинди дә булса сәбәп аркасында). — *Иртә белән --- бия колын салган.* Т. Гыйззәт.

КОЛЫНЛАУ *ф.* Колын тудыру. *Кайберәүләрнең бияләре кар эри башлагач та колынлады, язгы сабанга чыккач инде, авылда, һәр йортта диярлек, колыннар куренә торган булды.* Г. Ибраһимов.

КОЛЫНЛЫ *с.* Колынлаган, колыны булган. *Бу вакытта безнең бер колынлы бия белән бер атыбыз бар иде.* М. Гафури.

КОЛЫНЧАК *и. сөйл. к.* колын. *Ат баласы колынчак, билләрендә ыңгырчак.* Җыр. *Кыз — курчакка, малай колынчакка* [*тартыр*]. Мәкаль.

КОЛЬРА'БИ *и. бот.* Шалкан сыман сабаклы икееллык бакча үсемлеге — кәбестәнең бер төре; шалкан кәбестә. *Кольраби тиз өлгерүе һәм салкынга чыдамлы булуы белән аерылып тора.* Җиләк-җимеш...

КОЛЬТ *и.* Револьвер яки пулемётның бер төре.

КОЛЬЧУ'ГА *и. тар.* Вак металл бөжралардан эшләнгән борынгы сугыш киеме.

КОЛЯ'СКА *и.* 1. Ачыла һәм ябыла торган өслеге булган сиртмәле тарантас. *Ул чагында бит* [*Садыйк бай Кигәвенлегә*] *ялтыравыклы коляскага өч ат җигеп, кыңгыраулар белән дөньяны зырлатып килә торган иде.* Ш. Камал.

2. Кечкенә баланы саф һавада йөртү өчен көймәле кечкенә арба. *Гафиятнең төпчеге Рөстәм --- коляска кырыена тотынып басты.* Г. Ахунов. *Коляска белән бала тартып чыккан яшь хатыннар балаларын кояшка каршы куйганнар да үзләре сөйләшәләр.* И. Гази.

3. Махсус кечкенә арба. *Мотоцикл коляскасы.* □ *Аяксыз булганга, Фатих әмирханны, коляскага утыртып, малайлар этеп йөртәләр иде.* М. Гали.

КОЛЯ'СКАЛЫ *с.* Коляска тагылган. *Коляскалы мотоцикл.*

КОМ [ком] *и.* 1. Кварц яки башка каты минералларның таралып торган бөртекләре, ярмалары. *Елга комы. Диңгез комы. Балчыклы ком. Юлга ком сибү.* □ *Көймә, яр читенә җиткәндә генә, комга терәлде.* Г. Гобәй. *Олы юлдан атлар чаба, Ком бураның туздырып.* Г. Камал.

2. Ике составлы кайбер ботаник һәм зоологик атамаларның беренче кисәге. *Ком солысы. Ком үләне. Ком еланы.*

Ком сәгате — үзара нечкә көпшә белән тоташтырылган ике пыяла савытчыкның берсеннән икенчесенә билгеле бер вакыт арасында ком коелып тора торган прибор (кечкенә вакыт берәмлеген билгеләү өчен, мәсәлән, медицина процедураларында кулланыла). **Ком төс** — соргылт сары төс. [*Шахтёр җизнинең*] *башында ком төслерәк эшләпә.* Г. Галиев.

◇ **Ком бураны уйнату (күтәрү, туздыру)** — бик нык тавышлану, тиргәшү. *Иртән ком бураны күтәрергә хәзерләнә торгандыр* [*Сөләйман абзый*]. *Ул бит барысын да эшли ала!* Г. Әпсәләмов. **Ком гарәбе кебек** — кап-кара булып. *Хәбирнең иптәш малайлары көнозын Идел буенда яттылар, ком гарәбе кебек каралыштылар.* Ш. Хөсәенов. **Ком диңгезе** — комлы сахра, чүл. *Ераста дөяләр кәрваны бара. - - - Бу батыр мосафирлар, адым саен сине йотарга торган ком диңгезен җиңеп, кеше белән кеше арасындагы мөнәсәбәтне тоташтыралар.* Каз. утл. **Ком коелу** *ирон., шаяр.* — картаю, хәлсезләнү. — *Ибраһим абыегыз картаеп бара, комы коела башлады.* Х. Вахит. **Комга корылган** — нигезсез, тормышка ашуы мөмкин булмаган. *Комга корылган план.* **Комга утыру (утырту)** — алдану (алдау); авыр хәлдә калу (калдыру). *Герасимов - - - бу кадәр комга утырып калуына һаман ышана алмый иде.* Г. Ибраһимов. — *Өченче - - - полк безне комга утыртты ахры.* Ш. Усманов. **Комнан аркан ишү** — файдасыз, нәтиҗәсез эш белән шөгыльләнү яки эшсез тик йөрү турында. *Дүртенче көн бөтен бер бригада комнан аркан ишә.* Б. Камалов. **Комнан ишелгән** — файдасыз, тормышка ашмый торган. *Планнар корган буласың, - - - хыял челтәрләре үрәсең, бактың исә, үргәнең комнан ишелгән булып чыга.* Э. Касыймов.

КОМ-I Кушма сүзләрдә „коммунистик“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **компартия, комвуз, комклуб, комбригада.**

КОМ-II Кушма сүзләрдә „командир“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **комдив, комсостав.**

-КОМ Кыскартылган кушма сүзләрдә „комитет“ мәгънәсендәге икенче кисәк, мәсәлән: **райком, профком.**

КО'МА *и. мед.* Аңны югалту һәм организмның тышкы тынычсызлауларга булган реакциясе кискен йомшару белән бәйләнгән авыру.

КОМАГАЙ *с. сөйл.* **1.** Комсыз, ашап туймый торган. *Шәмсинең белүенчә, әхмәди абзасы ашау-эчү мәсьәләсендә алай комагай түгел.* Г. Бәширов. *Борын-борын заманда бар иде ди бик комагай бер бүре.* Әкият. /*и. мәгъ. Комагайның борыны кырык көн алдан кычыта.* Мәкаль.

2. *күч.* Булганы, ирешелгән кадәресе белән канәгатьләнмәүче; ертлач. *Аңгы иле алагай, Борнак иле комагай.* Әйтем. || Үз файдасын гына кайгыртучы.

КОМАГАЙЛАНУ *ф. сөйл.* Комагайлык күрсәтү, комсызлану. — *Кешедә ашаганда артык комагайланып утырма, алдыңда һәрвакыт оятлылыкка аз гына калдыра торган бул.* Ф. Хөсни. *Кара бозау - - - әнисенең җиленә төртә-төртә, комагайланып имүен белә.* С. Рафиков.

КОМАГАЙЛЫК *и. сөйл.* Комагай булу сыйфаты. *Ала сыер бик зур комагайлык белән әнә шул бәрәңгене ашарга тотына.* Г. Галиев. *Комагайлык максатларыннан югары торган, - - - йөз аклыгы булган ирекле хезмәт — менә шул дөньяда торуның идеалларыннан берсе булырга тиеш.* Г. Халит.

КОМАЙ: комай үләне *бот.* — дымлы урыннарда үсә торган әре себерке чәчәкле күпьеллык азык үләне; *русчасы:* манник обыкновенный.

КОМАК *и. диал. к.* күсе. *Немецлар, дотларына кереп, комак шикелле урнашканнар да һич кенә дә чигенергә теләмиләр иде.* Каз. утл.

КОМАЛАК *и.* **1.** *диал. к.* колмак.

2. *иск.* Кипкән куй тизәге (күрәзәлек итүдә рәмел ташы урынына кулланылган). [*Дивананың*] *бер кулында думбра, бөрсендә яулык белән төрелгән такта һәм вак рәмел ташлары—комалаклар иде.* Г. Ибраһимов.

◇ **Комалак ачу (салу)** *иск.* — комалак белән күрәзәлек итү. [*Зифа:*] *Син комалак сала беләсеңме?* М. Фәйзи.

КОМАЛАКЧЫ *и. иск.* Комалак белән күрәзәлек итүче. [*Җолкынбай:*] *Әнә шул комалакчыны китерегез, мине ул күрде, ышанмасагыз, аңардан сөйләтегез.* Г. Ибраһимов.

КОМА'НДА I *и.* **1.** Уставта кабул ителгән формада телдән бирелә торган кыска приказ (армиядә, флотта). — *Командагызны көтәм, иптәш командир!* Г. Гобәй. — *Сафка тезелергә команда булды.* Г. Әпсәләмов. || Күрсәтмә, боерык. [*Бикташев*] *Һәр урында команда бирергә ярата.* М. Җәлил. *Нәсимә командасында - - - табын хәзерләнде.* Ш. Камал.

2. Зур булмаган хәрби часть, подразделение, отряд. *Хәрби хуҗалык командасы.* □ *Командалар сафка тезелә башладылар.* А. Расих. [*Вахитов:*] *Иптәш Хәтми, сиңа боерам: хәзер үк минем махсус командамны ал, 130 кешең белән Поповка юлына чык, моннан полк барып җиткәнче позиция тот.* Н. Исәнбәт. || Судноның барлык матрослары. *Комиссар Маркин һәр корабның яуга әзерлеген үзе тикшерергә, командалар белән сөйләшеп чыгарга кирәште.* С. Сабиров. *Пароход командасы тырыш матросны бик яратты.* Г. Минский. || Билгеле бер эшне башкаручылар төркеме. *Янгынчылар командасы.* □ *Мин - - - Тимур командасының чиксез мактауга лаеклы хезмәтен күрәм.* Г. Гобәй. || *сөйл.* Бер төркем, компания.

3. Спорт коллективы. *Совет спортчылары командасы. Хатын-кызларның җыелма баскетболчылар командасы.* □ *Бүген кич безнең* [*футболчылар*] *Зеленодольскида хуҗалар командасы белән очраша.* Г. Мөхәммәтшин.

Команда пункты — *к.* командалык пункты. *Полк командирын һәм Гәрәевне полк команда пунктына чакырып алдылар.* А. Шамов.

КОМА'НДА II *и. иск. сөйл.* **1.** Командир, баш кеше. *Тирече Вәли элек тә команда, хәзер совет чорында да команда.* Г. Ибраһимов. *дүвәл заманда, кәҗә команда, үгез адмирал, бүре генерал - - - булган заманнарда, бер патша яшәгән, ди.* А. Алиш. || *с. мәгъ.* Хәрби командирлар хәзерли торган.— *Менә мин, команда мәктәбен бетереп, кызыл командир булып чыктым.* Ф. Бурнаш.

КОМА'НДАДАШ *и.* Кем белән дә булса бер үк командадан I (2, 3 мәгъ.) булган кеше. || *с. мәгъ.* Кем белән дә булса бер үк командада булган. [*Тамараның*] *командадаш иптәше Юрий Антонов, 15 километр араны 52 минут 9 секунд үтеп, беренче урынга чыкты.* Соц. Тат.

КОМА'НДАЛЫ *с.* Командаларга бүленеп, кара-каршы ярышып уйнала торган. *Командалы уеннар.*

КОМА'НДАЛЫК *и.* Нинди дә булса хәрби частька җитәкчелек. *Илсөяр тоткыннарга Костин командалыгындагы партизаннарның батыр һөҗүмнәре турында сөйли башлады.* Г. Гобәй. || *сөйл.* Гомумән нинди дә булса эшнең, коллективның башында тору, җитәкчелек итү. *Командалыкны үз кулына алу.*

Командалык итү — 1) хәрби отрядның, берләшмәнең командиры булу. *Дә бит гражданнар сугышы чорында унсигез яшьләре дә тулмаган яшүсмерләр гаскәр белән командалык иткәннәр.* Г. Ахунов; 2) *сөйл.* нәрсәгә дә булса җитәкчелек итү, нәрсәнең дә булса җитәкчесе булу; 3) *шелт.* үз вазифасына карамаган эшкә тыгылып, күрсәтмә, боерык биреп йөрү турында. [*Дилбәр Галиевна*] *бөтен больницаны дер селкетеп тора ич. Бөтенесе белән командалык итә. Бөтен хезмәткәр, хәтта Ибраһим абый үзе дә аңа буйсына ич.* Х. Вахит. **Командалык пунктысы** — сугыш белән җитәкчелек итү урыны. *Без командалык пунктына кайтканда, караңгы төшкән иде инде.* Каз. утл.

КОМАНДАН *и. иск.* Гаскәр башлыгы; командир; хәрби флот капитаны. [*Фон дер Гольц*] *кайзер Вильһелмның Төркиядәге баш команданы иде.* Н. Исәнбәт. *Ул үзен, бер экономика философы булудан бигрәк, колхозлашу фронтының билгеләнгән команданы дип белә.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КОМАНДАРМ *и.* Армия командующие. *Командармның --- безнең хәлне сорашып, күрсәтмәләр биреп торуы тикмәгә генә түгел, бәлки дивизиянең иң җаваплы һәм кыен участокта булуыннан иде.* Каз. утл.

КОМА'НДАЧЫЛЫК *и.* Команда, боерык бирү ысулы белән генә эш итү. *Командачылыкка юл куймау.*

Командачылык итү — команда, боерык бирү ысулы белән генә эшләү. [*Пионерларны эшкә оештыруда*] *командачылык итү шарт түгел.* М. Җәлил.

КОМАНДИР *и.* Хәрби частьның, суднoның начальнигы, башлыгы. *Рота командиры. Орудие командиры.* □ *Командир, команда бирү өчен, үзәңгеләренә басып күтәрелә төште.* А. Шамов. || Нинди дә булса предприятиенең җитәкчесе, башлыгы. — *Йомышчы малай кебек чабып йөрү — производство командирының эше түгел. Оештыра һәм таләп итә белергә кирәк.* Г. Әпсәләмов. || *сөйл.* Нинди дә булса компаниянең, төркемнең башында торучы, оештыручы кеше. *Мин бөтен компаниягә балык тотуларда, урманга, тауга җиләккә йөрүләрдә командир булдым.* Г. Ибраһимов.

КОМАНДИРЛА'РЧА *рәв.* Командир кешегә хас булганча, командирдан таләп ителгәнчә. *Бәлки, [Галим] бүген беренче мәртәбә чын командирларча хәрәкәт иткәндер.* Г. Әпсәләмов.

КОМАНДИРЛЫК *и.* Командир хезмәте, вазифасы. [*Шакирга*] *ничектер командирлык килешеп тә тора кебек иде.* М. Әмир. *Гафур — шушы арада гына кызыл-армеецлар арасыннан командирлыкка күтәрелгән батыр --- егет.* Ш. Усманов. || *с. мәгъ.* Командир эшенә бәйләнешле, командирга мөнәсәбәтле. *Командирлык тәҗрибәсе.* || Командирларга хас, командирларда була торган. *Полковник үзенең командирлык билгеләрен өзеп ташлый.* Н. Дәүли.

Командирлык итү — командир вазифасын үтәү, командир булу. *Менә, елдан артык инде, өлкән лейтенант Поляков безгә командирлык итә.* Ә. Еники.

КОМАНДИРО'ВКА *и.* 1. Эш урыныннан кая да булса (башка шәһәргә, районга, өлкәгә) барып кайту белән бәйләнешле хезмәт йомышы. *Бүген Казаннан командировкадан кайттым.* М. Җәлил. *Бигрәк көтелмәгән, кинәт чыгып китәргә туры килгән командировка булды ла бу.* Л. Ихсанова. || Хезмәт йомышы белән кая да булса бару. *Истәлекләр әнә шул командировка юлында — 1925 елның июль һәм август айларында тудылар.* Г. Галиев.

2. *сөйл. к.* командировка таныклыгы. *Командировкага билге ясату.*

Командировка акчасы — командировка (1 мәгъ.) чыгымнары өчен бирелә торган акча. **Командировка таныклыгы** — хезмәт йомышы белән җибәрү турында кемгә дә булса бирелгән таныклык.

КОМА'НДОВАНИЕ *и.* Гаскәр башында торучы кешеләр. *Капитан Кравченко --- үзләренә командование тарафыннан әһәмиятле, җаваплы бурыч куелуы турында сөйләде.* А. Әхмәт.

КОМАНДОР *и.* 1. *тар.* Урта гасырлардагы руханирыцарь орденнарында югары дәрәҗәләрнең берсе; шул дәрәҗәгә ия булган кеше.

2. *спорт.* Яхт-клуб председателенең дәрәҗә исеме; шул дәрәҗәгә ия булган кеше (кайбер Көнбатыш Европа илләрендә, АКШта, шулай ук 1926 елга кадәр — СССРда). || Ат, чаңгы, автомобиль һ. б. ш. ярышларның җитәкчесе.

КОМА'НДУЮЩИЙ *и.* Эре гаскәри берләшмәнең начальнигы, командиры. *Флот командующие.* □ *Телеграммада фронт командующиеның имзасы куелган иде.* Ш. Усманов.

КОМАР *и.* 1. *иск.* Отышлы уен, акча уены.

2. Дәрт, нык мавыгучанлык, һәвәслек. *Аучылык комары.* □ *Партизаннарның көннән-көн ныгый баруын күрсәләр дә, интервентлар, бай Ерак Көнчыгышны талау комарыннан исереп, бөтенләй басып алу хыялында яшиләр иде.* И. Туктар. *Хәзер инде миндә бу табышмакны чишү телләге һәм шуның үзенә күрә бер комары үсә иде.* Г. Минский. || *с. мәгъ.* Оста, һәвәс (сүзгә, көлке-мәзәккә). *Мин анысы борын-борыннан сүзгә комар кеше.* И. Гази.

3. Кызыклык, мәзәклек, мавыктыручанлык. *Көлүләр тукталдылар, сүзләр дә әүвәлге мәгънә вә комарларын җуйдылар.* Ф. Әмирхан.

4. *с. мәгъ. к.* комсыз 2. *И комар мин яшәү кызыгына.* Н. Арсланов.

КОМАРЛАНУ *ф.* Комсызлык (2 мәгъ.) күрсәтү, комсызлану. /*рәв. мәгъ. Яңгыр көтә җир йөзе комарланып.* Дәрдмәнд.

КОМАРЛАНЫП *рәв.* 1. Комар (2 мәгъ.) белән, дәртләнеп, бик нык мавыгып. *Гайнуллин, комарланып, [диабазны] бораулый да бораулый.* М. Хөсәен. [*Фоат*] *үзенең --- спорт уңышларын сөйләргә, комарланып мактанырга тотынды.* Ш. Маннур.

2. *күч.* Бик нык кызыксынып, йотылып. *Минем ипташләр --- фронтларда, лазаретларда булган аерым хәлләрне сөйләвемне комарланып тыңлыйлар иде.* А. Таһиров. [*Ханым*], *Жаденконың шактый комарланып карап торуыннан уңайсызланып, --- ишеккә табарак тартылды.* А. Гыйләҗев.

КОМАРЛЫ *с.* 1. *иск.* Отышлы, акчалы. *Комарлы уеннар уйнау.*

2. Дәртле, оста, һәвәс. *Уенга комарлы кеше.*

3. *күч.* Кызыктыргыч, мәзәк, мавыктыргыч. *Комарлы мажаралар сөйләү.*

КОМАРЛЫК *и. к.* комар (2,3 мәгъ.). *Оп-олы кешеләр, сугышу комарлыгы белән тәмам онытылып, бер-беренә һөҗүм итәләр.* А. Расих. [*Муса*] *инде яңадан көрәш комарлыгына ташланган кеше иде.* Ш. Маннур. *Хәзер [бүреләрне] һавадан атып йөриләр, имеш. Моның ни кызыгы да ни комарлыгы бар.* Ә. Еники.

КОМАРЛЫЛЫК *и.* 1. Комарлы (1, 2 мәгъ.) булу сыйфаты. *Отышлы уеннарга комарлылык. Комарлылык белән эшкә тотыну.*

2. Комсызлык. *Комарлылыкка юл куймау.*

КОМАЧ *с.* 1. Ачык кызыл. [*Әни*] *өстенә зәңгәр бизәкле матур күлмәген кигән, башына шундый ук зәңгәргә комач бөрчек төшкән матур яулык бөркәнгән.* Р. Төхфәтуллин. *Кояш байый кереп комач төскә.* Ш. Маннур.

2. *и.* Шундый төстәге киҗе-мамык тукыма. — *Лавкалар ачып, комачлар сата алмыйлар хәзер [байлар].* С. Рафиков. || *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Җаныем теккән комач күлмәк күземә тар күренә.* Җыр.

3. *и. иск.* Кызыл әләм. [*Пароходның*] *моржа янындагы колга башында --- комач җилфердәде.* К. Нәҗми.

КОМАЧАУ *и.* Уңайсызлык, кыенлык, тоткарлык. *Комачау тудыру.* □ *Шундый ашыккан вакытта комачавы да чыгып тора тагын.* А. Алиш.

Комачау итү — комачаулау. — *Син патефон уйната тор, — диде Ильин, миңа таба борылып, — уйнат, уйнат, безгә комачау итми ул.* И. Гази.

КОМАЧАУЛАУ *ф.* Уңайсызлау, кыенлык тудыру; тоткарлык ясау. — *Үзеңә тапшырылган эшне эшлә. Кешеләргә комачаулап йөрмә.* Ш. Камал. *Уйнаклап искән җил көймәгә алга барырга комачаулый.* Г. Гобәй.

КОМАЧАУЛЫ *с.* Уңайсыз, кыен. *Комачаулы эш.* | *рәв. мәгъ. Тиздән әдәбият кичәсе куймакчылар, --- тик менә рөхсәт ягы гына комачаулы күренә.* Г. Ибраһимов.

КОМАЧАУЛЫК *и. к.* комачау. *Без бабайның эшенә бервакытта да комачаулык китерми идек.* Г. Гали. — *Чигенүче эшелоннарның юлында берәр төрле комачаулык чыга калса, революция алдында җавап бирәчәксез.* Ш. Усманов.

Комачаулык итү (ясау) — комачаулау. *Без кешегә яшәргә комачаулык итмибез.* А. Шамов. *Күләгәдә озын булып үскән үләннәр, урын-урын аякка уралып, [атларга] бераз комачаулык ясыйлар.* Ш. Камал.

КОМАЯК *и. диал.* Елга буендагы вак, чиста комлы яр буе.

КОМАЯКЛЫ *с. диал.* Комлы. [*Көймәче безгә*] *кояшта кызыныр һәм суга төшәр өчен дә уңайлы булган комаяклы җирләргә барырга юллар өйрәтте.* С. Кудаш.

КОМБАЙН *и.* Бер үк вакытта берничә машина эшен башкара торган катлаулы агрегат. *Күмер комбайны. Үзйөрешле комбайн.* □ *Комбайн игенне урып китә, безнең машина шуның артыннан ук [саламны] эскертләп бара.* Р. Төхфәтуллин.

КОМБА'ЙНЧЫ *и.* Комбайн йөртүче. [*Зәйтүнә:*] *Юк инде, минем комбайнчы буласым килә.* Т. Гыйззәт.

КОМБАТ *и.* **1.** Батальон командиры. *Комбатның ординарецы Исаев [вагонда] югарыгы киштәнең почмагында урнашкан.* Ш. Усманов.

2. Батарея командиры.

КОМБЕД *и.* Ярлылар комитеты. *Җыелыштагы ярлыюксылларның күбесе комбедлар --- аша Советның ярдәмен күргән кешеләр иде.* С. Рафиков.

КОМБИАЗЫК *и.* Төрле туклыклы матдәләрне, минераль тозлар һәм витаминнарны тиешле микъдарда кушып әзерләнгән терлек азыгы. *Комбиазыкларны химик эшкәртү.* □ *Комбиазыкларны кәгазь капларга салалар, я брикетлап чыгаралар.* А. Расих.

КОМБИЖИР *и.* Төрле катнашмалардан торган май.

КОМБИНАТ *и.* Технологик процесслары буенча берберсенә бәйләнешле берничә промышленность тармагын үз эченә алган эре предприятие. *Ит-сөт хәзерләү комбинаты. Балык комбинаты.* □ *Сегежа — кечкенә генә эшче шәһәрчек, сугышка кадәр анда кәгазь комбинаты эшләгән.* Г. Әпсәләмов. || Урындагы вак промышленность һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре берләшмәсе. *Фәсхи уйлаганча, Өчнарат трактор-машина станциясе совхоз-колхоз комбинаты булып чыкмады.* Ф. Сәйфи-Казанлы. || Капиталистик илләрдә: теге яки бу монополия белән конкуренция алып бару максатыннан чыгып төзелгән төрле предприятиеләрне үз эченә алган берләшмә.

КОМБИНА'ТОР *и.* Комбинацияләргә (2 мәгъ.) оста кеше, төрле комбинацияләр ясый белүче; комбинацияләр һәвәскәре. — *Сез кем? Җитәкчеләрме, әллә Остап Бендер кебек төрле махинация белән шөгыльләнүче комбинаторлармы?* М. Хәсәнов.

КОМБИНАТО'Р *с. махс.* Комбинацияләүгә нигезләнгән. *Комбинатор анализ. Авазларның комбинатор үзгәрешләре.*

КОМБИНАЦИОН *с.* **1.** Комбинациягә (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле. *Комбинацион таблица.*

2. *спорт. к.* комбинацияле. *Комбинацион уен* (мәсәлән, футбол, шахмат уеннарында).

КОМБИНА'ЦИЯ *и.* **1.** Күбесенчә бер төрдән булган нәрсәләрнең билгеле бер тәртиптә урнашуы, берләшүе, кушылуы. *Авазлар комбинациясе.* □ [*Габбас:*] *Иптәшләр, табигатьтәге иң матур төсләр комбинациясен чагылдыра торган яңа рецептура ачтым.* Ш. Камал. [*Югарыда китерелгән*] *цифрлардан комбинация ясаштырып, аларның үзлексез хәрәкәтләрен күз алдына китерсәң, Париж урамындагы хәрәкәт картинасы турында --- бер фикергә килүе авыр булмас.* Г. Гали.

2. *күч.* Берәр максатка ирешү өчен эшләнә торган күптөрле мәкер-хәйлә, катлаулы алымнар системасы. *Салкын акылның хәйләкәр комбинацияләре Заһиднең һәрбер эшен акылый иде.* А. Расих.

3. *спорт.* Яхшы нәтиҗәгә, җиңүгә, өстенлеккә ирешү өчен эшләнгән уен, хәрәкәт алымнары системасы. *Шахмат уенындагы комбинацияләр. Снарядта бер үк комбинацияне күп тапкыр кабатлау.*

4. Хатын-кызның эчке күлмәге. [*Хәдичә*] *алды челтәрләп чигелгән ефәк комбинация* [*өстеннән*] *рәешкә генә тота торган бердәнбер көрәнсу йон күлмәген киде.* М. Хәсәнов.

КОМБИНА'ЦИЯЛЕ *с.* Нинди дә булса комбинациядән (1, 3 мәгъ.) торган. *Комбинацияле сөрү агрегаты. Комбинацияле йөзү. Комбинацияле уен.*

Комбинацияле һөҗүм — төрле хәрби частьларның бергәләп катнашуында алып барылган һөҗүм. *Егерме өченче августта гитлерчылар шәһәрне алу өчен беренче комбинацияле һөҗүм башладылар.* С. Шакиров.

КОМБИНА'ЦИЯЛӘШТЕРҮ *ф. к.* комбинацияләү.

КОМБИНА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Комбинация (1 мәгъ.) ясау.

КОМБИНЕЗОН *и.* Куртказы белән чалбары тоташ итеп тегелгән кием. [*Гарифуллә*] *майланып беткән комбинезонын сала башлады.* Э. Касыймов. *Безнең өстә җылы тун, ак комбинезон, башта малахай бүрек.* Г. Әпсәләмов.

КОМБИСИ'ЛОС *и.* Төрле туклыклы үлән азыклары һәм витаминга бай матдәләр катнашмасыннан торган силос. *Бозаулар өчен махсус салдырылган комбисилос әйбәт сыйфатлы булып чыкмаган.* А. Расих.

КОМБРИГ *и.* Бригада командиры. *Полк, комбриг приказында күрсәтелгән вакыт эчендә, үзенә билгеләнгән пунктка барып җитте.* А. Шамов.

КОМДИВ *и.* Дивизия командиры. *Мин комдив белән штаб начальнигының җылы каршылавыннан бик канәгать булып калдым.* Каз. утл.

КОМГАН *и.* Төрки халыкларда җиз һ. б. төрле металлдан эшләнгән тоткалы һәм борынлы кувшин сыман савыт (юыну өчен файдаланыла). *Мич белән ишек арасында зур җиз таз, эреле-ваклы берничә җиз комган тора.* Г. Ибраһимов. *Хәмидә әби комганга җылы су салып куймаган өчен дә* [*Фәхри бабайның*] *авыр сүзләрен ишетә.* М. Гафури.

КОМЕДИАНТ *и. иск.* Актер, артист. || Циркта, балаганда көлкеле рольләрне башкаручы артист; комик.

КОМЕДИО'ГРАФ *и.* Комедияләр язучы драматург. *Безгә комик ситуацияләргә нигезләнгән җитди конфликт кирәк. Комедиографлар җиңел юлдан бармасыннар иде.* И. Гази.

КОМЕ'ДИЯ *и.* **1.** Көлкеле һәм күңелле әхтәлекле яки сатирик сюжетлы драма әсәре. *„Беренче театр"* —

татар сәхнәсенең классик әсәре булып кала торган комедия. М. Гали. || *күч.* Көлкеле, кызыклы вакыйга, күренеш, мажара. [*Кадимчеләрнең*] *үзләрен генә гакыллы, үзләрен генә туры санап сөйләгәннәрен рәхәтләнеп тыңлап торам инде мин. Акчасыз комедия.* Ф. Әмирхан. *Ләкин мондый* [*төрекчә сөйләшеп маймылланып йөрү кебек*] *комедияләр вакытында булды да, узды да китте.* Г. Тукай.

2. Кемнең дә булса алдында билгеле бер максат белән икейөзләләнү, ялагайлану, риялану кыланышы. [*Корбан:*] *Хатип әфәнде, без үлем сугышы алдында, безгә комедия кирәкми.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КОМЕ'ДИЯЧЕЛ *с.* Комедиягә хас. *Җәләл белән Габделхакның комедиячел характеры әсәрне игътибар белән укыган кешегә күренми калмаска тиеш.* И. Нуруллин.

КОМЕНДАНТ *и.* 1. Хәрби крепость яки ныгытылган районның начальнигы. *Комендант --- бер унтер-офицәр белән ун солдатны Васьканы әзләргә җибәргән.* М. Гали.

2. Гарнизон һәм каравыл хезмәтләрен төгәл үтәүне, хәрби хезмәткәрләрнең җәмәгать урыннарында үз-үзләрен тотуларын күзәтү кебек эшләргә җитәкчелек итүче хәрби башлык. *Гарнизон комендантты. Лагерь комендантты.* □ *Шәһәр комендантты Архипов дхмәтне салкын гына каршы алды.* Ш. Камал.

3. Аралашу юлларында: гаскәрнең, хәрби кешеләрнең һәм хәрби йөкләрнең дөрес хәрәкәт итүен күзәтеп торучы. *Вокзалның хәрби комендантты* [*Мөнирәгә*] *поездның кайсы тупикта торганлыгын әйтте.* Г. Әпсәләмов.

4. Нинди дә булса учреждениегә караган яки учреждение урнашкан йортның идарәчесе. *Тулай торак комендантты.* □ *Бер атнадан соң тимер юл йортлары комендантты аларның квартирасына килә.* А. Шамов.

Комендант сәгате — билгеле бер сәгатьләрдә махсус рөхсәттән башка халыкка урамга чыгып йөрүне тыю (сугыш яки хәрби чолганыш вакытында). *Шәһәрдә кич 6 сәгать 30 минуттан комендант сәгате тәртипләре саклану.*

КОМЕНДАНТЛЫК *и.* Комендант хезмәте. *Комендантлыкка билгеләү.*

КОМЕНДАТУ'РА *и.* Комендант житәкчелегендәге учреждение; шул учреждение урнашкан бина. *Утыртып китерүе өчен шоферга рәхмәт әйтеп саубуллашкач, комендатура урнашкан өйне табу нияте белән атлап киттем.* Г. Минский. *Комендатура ишегенә һәм тагын берничә җиргә зур-зур белдерүләр кадакланды.* М. Шабай.

КОМЕНДОР *и. махс.* Матрос-артиллерист. — *Мин үзем — Балтикада дүрт ел хезмәт иткән комендор.* С. Сабиров.

КОМЕ'ТА *и. астр.* Якты томан белән өртүле яктыртkыч үзәге һәм койрык сыман якты полосасы булган күк җисеме; койрыклы йолдыз. *Якты кометаларны гади күз белән дә бик яхшы күрергә була.* Астрономия.

КО'МИ *и.* Угро-фин теле группасыннан Коми АССРда яшәүче төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе.

КОМИЗМ *и.* Кешеләрдә, төрле эш-хәлләрдә, вакыйгаларда көлкеле яклар; көлкелек, юмор. *Драма булуына карамастан,* [*„Бәхетсез егет"тә*] *комизм элементлары да күп кенә урын алып торалар.* М. Гали.

КО'МИК *и.* 1. Көлке рольләрне башкара торган артист. *Лосев сәхнәдә чын комиклардан бер дә ким уйнамады.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Көлкеле рольләрне башкаруга бәйләнешле. *Комик талант. Комик роль.*

2. Мәзәк кеше, мәзәкчел кеше. || *с. мәгъ.* Мәзәкчел, көлкеле. *Комик сюжет. Дәрнең комик ситуацияләргә бай булуы.*

3. *иск.* Комедияләр авторы.

КО'МИКЛАНУ *ф.* Кәмитләнү, кыланчыклану.

КОМИКЛАРЧА *рәв.* Комикларга (1 мәгъ.) хас булганча.

КО'МИКЛЫК *и.* Комик булу, мәзәклек, көлкелек.

КОМИНТЕРН *и.* Коммунистик интернационал. *Коминтерн байрагы астында Эшче сыйныфы җиңеп чыгачак!* М. Гафури.

КО'МИ-ПЕРМЯК *и.* Пермь өлкәсендә Коми-пермяк милли округында яшәүче төп халык атамасы, шул халыкның бер кешесе.

КОМИССАР *и.* 1. Политик, административ яки хуҗалык эшләрен үтәүгә хөкүмәт тарафыннан аерым вәкаләтләр бирелгән югары хезмәт урынындагы эшлекле. *Мәгариф комиссары. Хәрби комиссар.* □ [*Гаврилов:*] *Вакытлы хөкүмәт юк инде. Власть Советлар кулында. --- Халык Комиссарлар Советы сайланган. Комиссарлар Советының председателе ипташ Ленин.* Ш. Камал. *Җәүдәтнең әтисе элек көньяк өязларнең берсендә комиссар булып эшләгән иде.* Г. Бәширов.

2. 1918—1942 елларда Совет Армиясе хәрби-политик хезмәткәрләренә бирелә торган звание; шул званиегә ия булган кеше. *Батальон комиссары. Дивизия комиссары.* □ [*Әйдүк*] *комиссарны да, тирә-ягын чорнап алган командирларны да үзенең иң якын кешеләре итеп хис итте.* Һ. Такташ.

3. XVIII—XIX йөзләрдә чит илләрдә һәм Россиядә: полиция функцияләрен үтәүче чиновник; пристав.

КОМИССАРИАТ *и.* Башында комиссар торган кайбер дәүләт яки административ учреждениенең атамасы. *Комиссариат хәрби оешмалар белән тыгыз элемтәдә була, фронтта мөселман солдатлары арасында зур политик эш алып бара.* Каз. утл. *Җәй урталарында* [*Гәрәйне*] *хәрби комиссариатка чакыралар.* Г. Мөхәммәтшин.

КОМИССАРЛЫК *и.* Комиссар вазифасы, хезмәте. [*Гыйлаҗи:*] *Комиссарлыктан мине коткарырсыз да зур йортлар, зур күперләр салу эшенә җибәрерсез.* Г. Ибраһимов.

Комиссарлык итү —комиссар булу. *Сабир комиссарлык иткән полк Казан аркылы үтә.* А. Шамов.

КОМИССИОН *с.* Комиссиягә (3 мәгъ.) бәйләнешле. — *Комиссион хакына килешә алсак, мин сиңа йортыңны алучы табам.* Т. Гыйззәт. || Арадашчы вазифасын үти торган, товарларны комиссиягә ала һәм сатып бирә торган. *Комиссион магазин.* || Комиссиягә (3 мәгъ.) бирелгән. *Комиссион товарлар.* || Комиссия (3 мәгъ.) тарафыннан билгеләнгән. *Комиссион бәяләр.*

КОМИССИОНЕР *и. махс.* Билгеле бер күләмдә түләү алып, сәүдә эшләренә, сәүдә килешүләренә арадашчылык итүче. *Портка килеп туктаган көнне үк безнең корабка комиссионерлар — төрле кибет һәм ферма вәкилләре килә башлады.* Р. Мостафин.

КОМИССИОНЕРЛЫК *и.* Комиссионер вазифасы, хезмәте. *Комиссионерлык белән шөгыльләнү.*

КОМИССИО'НКА *и. сөйл.* Комиссион магазин. *Минем хатын комиссионкада бер сәгать күреп кайткан. Менә ичмасам сәгать дисәң дә сәгать, ди.* Ф. Хөсни. — *Комиссионкага бик шәп пальто куйганнар.* Т. Гыйззәт.

КОМИ'ССИЯ *и.* 1. Нинди дә булса учреждение яки оешма карамагында махсус вәкаләтле берничә кешедән торган вакытлы яки даими орган. *Аттестация комиссиясе.* □ — *Хәзер мин участок сайлау комиссиясенә китәргә торам.* Г. Әпсәләмов. *Колхоз эшен тикшерергә комиссия төзелде.* К. Әмири.

2. Нинди дә булса махсус мәсьәләләрне чишү, башкару өчен хөкүмәт тарафыннан төзелгән дәүләт идарә итү органы. — [*Василий Петрович*] *кичә Мәскәүгә, Үзәк контроль комиссиясе пленумына китте.* Г. Ибраһимов.

3. *махс.* Билгеле күләмдә акчалата түләү исәбенә башкарыла торган сату-алу системасы. *Әйберләрне комиссиягә тапшыру.*

КОМИТАТ *и.* Венгриядә иң эре административ-территориаль берәмлек.

КОМИТЕНТ *и. махс.* Комиссионерга үз исеменнән нинди дә булса сату-алу эшләре башкарырга ышанып тапшырган кеше.

КОМИТЕТ *и.* **1.** Нинди дә булса эшкә җитәкчелек итү өчен сайлап куела торган коллегиаль орган. *Комсомол комитеты. Ярлылар комитеты. Стачкалар комитеты.* □ *Комитет тапшыруы буенча ул аерым заводларда татар эшчеләре арасында докладлар, беседалар үткәрә.* Ш. Камал.

2. Билгеле бер функцияләрне үтәү өчен төзелгән дәүләт идарә итү органы. *Министрлар Советы каршындагы физкультура һәм спорт эшләре комитеты. Хезмәт ияләренең шәһәр башкарма комитеты.* □ *СССР Үзәк Башкарма Комитеты карары буенча „Кызыл йолдыз“ колхозына Ленин ордены бирелгән.* К. Тинчурин.

КОМИТЕТЧЫ *и. сөйл.* Комитет (1 мәгъ.) члены. [*Муса:*] *Безнең ише --- комитетчылар бу тирәдә йөрми. Хәрби алманнар күп очракта куркыныч түгел: --- безнең телне белмиләр.* Ш. Маннур. [*Меньшевикларны*] *яклап әлекке комитетчылардан берничә сакаллы адвокат кына такылдады.* А. Расих.

КОМИЧА *рәв.* Коми телендә. *Комича сөйләшү.*

КОМҠАЗЫГЫЧ *и. зоол.* Комлы урыннарда оя ясап яши торган әлпә канатлы бөҗәк; *русчасы:* пескорой.

КОМҠАЗЫР *и. зоол.* Минога личинкасы; *русчасы:* пескоройка.

КОМКОР *и.* Корпус командиры. *Комкор дивизиягә сугышчан приказ тапшырды.* Каз. утл.

КОМҠОРСАҠ *и.* **1.** *сөйл. к.* ташбаш II (1 мәгъ.). *Комкорсак комлы суда булыр.* Мәкаль.

2. *күч. сөйл.* Шаян, шук, әрсез малай турында. *Разия чалбар балаклары манма су булган ике малайны — ике комкорсакны җитәклән кайтты.* Г. Ахунов.

КОМЛАНУ *ф.* Ком белән болганчыклану, ком катнашу. *Суга барсаң, иртәрәк бар: кичкә калсаң, комлана.* Җыр.

КОМЛАП *рәв.* Ком белән, ком катнаштырып. [*Яшь кызларның, яшь киленнәрнең*] *кайсы кое янында нидер чайкап-чайкап юа, кайсы рәшәткә буенда комлап, катыклап самовар агарта.* Ә. Еники.

КОМЛЫ *с.* Ком катнашкан, составында ком булган; ком белән капланган. *Комлы туфрак. Комлы су.* □ *Тау буеннан комлы юллар китә.* Н. Баян. *Комлы җил белән уралып, бар хәлгә чабып, шәһәрнең бер читеннән эскадрон килеп чыга.* А. Шамов. *Көймә комлы ярга килеп терәл[де].* Э. Касыймов.

КОМЛЫҠ *и.* Комлы, ком белән капланган урын. *Тирә-як саф комлык, бер якта очсыз-кырыйсыз җәелеп ялтырап яткан диңгез.* Ш. Камал. *Комлык артындагы яр буйлап параход күренде.* К. Нәҗми.

КОММЕНТА'ТОР *и.* Аңлатып бирүче, комментарийлар бирүче. *Комментатор бүлмәсе.* □ *Эпик әсәрләрдә --- укучыга комментатор да, экскурсиядәге кебек сөйләп йөрүче дә, әйдәп баручы да кирәкми. Ул вакыйгалар эчендә үзе яшәсен.* Г. Бәширов.

КОММЕНТА'РИЙ *и.* **1.** Нинди дә булса текстка аңлатма, искәрмә. *Комментарий бирү.* □ [*Панов:*] *Фронт хәлләрен белергә дә тоткыннарга җиткереп барырга кирәк. — Һәм шунда ук үз комментарийларыбызны да ясап барырга кирәк булыр, — диде Медведев, аңа өстәп.* Каз. утл.

2. Хөкем йөртүләр, берәр нәрсә турында ачыклаучы яки тәнкыйть күрсәтмәләр. *Матбугат комментарийлары.*

◇ **Комментарийлар кирәк түгел** — болай да аңлашыла.

КОММЕНТА'РИЙЛАУ *ф.* Комментарийлар бирү, аңлату. [*Бу юлларны*] *комментарийлап тору кирәкмәс.* Г. Гобәй.

КОММЕРСАНТ *и. махс.* Коммерция белән шөгыльләнүче кеше. *Сәфәр кебек оста коммерсантка сугыш шартларында үзен тәэмин итәрлек кенә юллар болай да --- җитәрлек иде.* Ә. Еники. — *Укымышым белән мин коммерсант.* Н. Исәнбәт. / *с. мәгъ. Иске китапчыларга алмашка буржуаз-демократик юнәлештә эш итүче коммерсант китапчылар килде.* И. Рәмиев.

КОММЕРСАНТЛЫК *и.* Коммерсант һөнәре, эше. *Әкрам бик тиз үзләштерде Коммерсантлык гадәтен.* Г. Насрый.

КОММЕ'РЦИЯ *и. махс.* Буржуаз җәмгыятьтә: сәүдә, сәүдә эшләре. *Шәфи --- Радом спекулянтлары белән итәк астыннан гына коммерция ясарга да өлгерде.* Ш. Маннур. — *Син миңа килеп чык әле. Миндә сиңа коммерция бар.* Т. Гыйззәт.

КОММЕ'РЧЕСКИЙ *с.* **1.** Коммерциягә бәйләнешле. *Коммерческий банк.* || *и. мәгъ. сөйл. к.* коммерческий училище. —*Гали хәзер коммерческийда укый.* Ф. Әмирхан.

2. Карточкалы тәэмин итү системасында югары бәяләр белән карточкасыз сату итә торган. *Коммерческий бәяләр.* □ *Каладә әллә нинди коммерческий кибетләр бар икән.* С. Рафиков.

Коммерческий директор — предприятиедә директорның тәэмин итү, сәүдә һәм хуҗалык-финанс эшчәнлегенең башка тармакларын алып баручы урынбасары. *Рәхим Дәүләтбаев — зур бер заводта коммерческий директор.* Р. Ишморат. **Коммерческий училище (мәктәп)** — революциягә кадәрге Россиядә: сәүдә хезмәткәрләре хәзерли торган урта уку йорты. *Коммерческий мәктәп студенты киемендәге Фәрит, Фатыйманың җирдәге чемоданын алып, --- яшел буяулы парадный ишеге төбенә алып китте.* Х. Садрый.

КОММИВОЯЖЁР *и.* Капиталистик илләрдә, берәр фирманың товар үрнәкләрен күрсәтеп йөреп, заказлар җыю эшен башкаручы сәүдә агенты. *Казанның татар байлары белән эш иткән сәүдә фирмаларының вәкилләре — коммивояжёрлар да шушы мөсафирханәләргә туктыйлар иде.* И. Рәмиев.

КОММУН *и. сөйл.* **1.** *к.* коммуна 1. [*Миңлесылу:*] *Карт, сиңа әйтәм, без дә язылыйк инде коммунга, әхмүш тә язылды.* Һ. Такташ.

2. Коммунист. *Галимҗан карт киявенең солдаттан коммун булып кайтуына риза түгел иде.* Г. Минский. / *с. мәгъ. Безнең яшьтә чакта алар шундый коммун йөрәкле, шундый югары идеяле --- гражданин булганнар.* М. Әмир.

КОММУ'НА *и.* **1.** Милек һәм хезмәт уртаклыгы нигезендә бергә яшәү өчен берләшкән кешеләр коллективы. *Хезмәт коммунасы.* □ *— Коммуна оештырабыз, иптәш. --- Авыл хуҗалыгы коммунасы.* Ш. Камал.

2. *сөйл. сир. к.* коммунизм 1. *Күмәкләшеп эшлиэшли Коммунага барабыз.* Җыр.

3. Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә кечкенә (башлангыч) административ-территориаль берәмлек.

КОММУНАЛЬ *с.* **1.** Коммунага (3 мәгъ.) бәйләнешле. *Коммуналь сайлаулар.*

2. Шәһәр хуҗалыгына караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Коммуналь хуҗалык.* □ *Сания иң элек коммуналь --- йортларда торучы кешеләр янына барды.* М. Әмир.

КОММУНАР *и.* 1. *тар.* Париж коммунасында катнашкан кеше. *Эйфель манарасын коммунарларга һәйкәл итәргә кирәк.* Г. Гали.

2. Коммуна (1 мәгъ.) члены. [*Бу бәрелештә*] *коммунарлардан Каюм һәм --- Мәхмүт үтерелделәр.* Ш. Камал.

КОММУНИЗМ *и.* 1. Социалистик революциянең җиңүе һәм пролетариат диктатурасы урнаштыру нәтиҗәсендә капитализмга алмашка килә торган югары ижтимагый-экономик формация (үзенең үсешендә ике фаза үтә: социализм һәм коммунизм). *Социализмның коммунизмга үсә баруы — объектив закончалык.* КПСС Программасы. *Һәрбер җиңү җәмгыятебезнең коммунизмга күчә баруын билгели һәм коммунизмга хас яңа сыйфат тудыра.* М. Җәлил. || Бу ижтимагый формациянең икенче, югары фазасы; „Һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хажәтенчә“ принцибына игезләнгән сыйныфсыз җәмгыять. *Коммунизм җәмгыятьнең сыйныфларга һәм социаль катлауларга бүленүен бетерәчәк.* КПСС Программасы.

2. Коммунистик җәмгыять төзү турында марксизм-ленинизм тәгълиматы. *Фәнни коммунизм.* □ *Коммунизмның кешелек белемнәренең суммасыннан килеп чыгуының үрнәген марксизм күрсәтә.* В. И. Ленин.

КОММУНИКАТИВ *с.* Коммуникациягә (2 мәгъ.) бәйләнешле. *Телнең коммуникатив функциясе.*

КОММУНИКАЦИОН *с.* Коммуникациягә (1 мәгъ.) бәйләнешле. *Коммуникацион корылмалар.*

КОММУНИКА'ЦИЯ *и.* 1. *махс.* Аралашу юллары (гадәттә армия белән аның базалары арасындагы әлемтә юлы турында). *Фронт коммуникациясенә әйләнгән бу юлны һәртөрле машиналар, йөк тарткычлар чокырчакырга әйләндереп бетергән.* Г. Минский. || Шәһәр коммуналь хуҗалыгының су, газ, җылылык һ. б. белән тәэмин итә торган корылмалары. *Җир асты коммуникацияләренең барысы да диярлек — җылылык челтәре, водопровод һәм газ трубалары — хәзер бер үк траншеяга урнаштырыла.* Соц. Тат.

2. *лингв.* Тел ярдәмендә аралашу, аңлашу, фикер һәм хис-тойгыларны белдерү.

КОММУНИСТ *и.* Коммунистлар партиясе члены. *Кешелек дөньясы тудырган барлык белем байлыклары белән зиһенеңне баетканда гына коммунист булырга мөмкин.* В. И. Ленин. [*Мостафа:*] *Мин моны чын коммунист сүзе итеп әйтәм. Минем өчен шуннан да югары сүз юк.* Ш. Камал.

КОММУНИ'СТИК *с.* 1. Коммунизмга (1 мәгъ.) бәйләнешле. *Коммунистик хезмәт бригадасы.* □ *Коммунистик җитештерү югары оешканлык, төгәллек һәм дисциплина булуны таләп итә.* КПСС Программасы.

2. Коммунизм принципларына нигезләнгән. *Коммунистик җәмгыять төзү.*

3. Коммунизм идеяләре белән сугарылган, шуларга таянып эш итә торган. *Коммунистик партия. Коммунистик тәрбия.* □ *Социализм һәм коммунизм төзү барышында коммунистик мораль яңа принциплар, яңа эчтәлек белән байый.* КПСС Программасы.

КОММУНИСТЛА'РЧА *рәв.* Коммунист кешегә хас булганча. [*Мәрьям Иштуганга:*] *Син коммунист бит. Коммунистларча эш ит.* Г. Әпсәләмов. — *Без бит коммунистларча яшәргә җыенабыз.* М. Шабай.

КОММУНИСТЛЫК *и.* Коммунист булу сыйфаты, хәле.

КОММУНХОЗ *и.* Коммуналь хуҗалык бүлеге. *Бүген бүлмәм өчен акча сорап Коммунхоздан килеп керделәр.* Һ. Такташ.

КОММУТА'ТОР *и. махс.* 1. Электр тогы үтә торган линияне тоташтыру һәм өзү, шулай ук токның юнәлешен үзгәртү приборы.

2. Телефон элемтәсендә төрле пунктлардагы телефон аппаратларын кул белән тоташтыру өчен эшләнгән махсус җайланма. [*Телефонда*] *Гөлчирә түгел, ә коммутатордагы телефонистка Шәмсия* [*сөйләшә*] *иде.* Г. Әпсәләмов.

КОММУТА'ТОРЛЫ *с.* Коммутаторы булган. *Коммутаторлы элемтә бүлеге.*

КОММУТА'ЦИЯ *и. тех.* Махсус аппаратура ярдәмендә электр тогының юнәлешен үзгәртү, алмаш токны даими токка әйләндерү.

КОММУТАЦИОН *с тех.* Коммутация өчен билгеләнгән. *Коммутацион аппаратура.*

КОММЮНИКЕ *и. полит.* Әһәмиятле халыкара мәсьәләләр турында хөкүмәтнең рәсми белдерүе. *Совет-Алжир уртак коммюникесы.*

КОМОД *и.* Тартмалары шудырмалы тәбәнәк шкаф (әчке кием һәм башка төрле вак-төяк әйберләр саклау өчен). *Рабига, урыныннан торып, комод тартмасыннан бер рәсем алып килде.* А. Шамов.

КОМПА'КТЛЫ *с.* Тыгыз, тыгыз укмашкан; җыйнак. *Компактлы масса.* □ *Шәһәрнең, компактлы итеп, егерме биш мең кешегә генә салынуы миңа ошый.* Г. Ахунов.

КОМПА'КТЛЫЛЫК *и.* Тыгызлык, тыгыз укмашканлык; җыйнаклык.

КОМПА'НИЯ *и.* 1. Вакытларын бергә үткәрү өчен яки нинди дә булса башка максат белән бергә берләшкән кешеләр төркеме. — *Шулай бервакыт без бер компания белән* [*көймәдә йөрергә*] *чыктык.* Ф. Әмирхан. *Галиәкбәр агайга үзенең белеш-таныш дуслары туры килеп, моны үзләренең компанияләренә чакырып утырттылар.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Предприятие тотучы капиталистларның сәүдә-промышленность берләшмәсе. — *Компания булып ачкан сәүдәсеннән* [*Ибраһим бай зур*] *табыш ясаган, ди.* Ә. Фәйзи. *Агыйдел, Кама буендагы иген сәүдәсе „Гыйрфан-Гали“ компаниясенә кереп бетеп бара.* Г. Ибраһимов. || Оешма башында торучының исеменә кушып әйткәндә шундый берләшмәдә катнашучыларга гомуми ишарә белдерә. *Мохтар* [*Габдуллага*] *сәүдә хезмәткәрләренең җыелышларына калмыйча йөрергә, Әхмәдиев һәм компаниясенең байлар файдасына хезмәт итүләрен һәрбер җыелышта ачып салырга тиешлекне әйтеп үтте.* Ш. Камал.

КОМПА'НИЯЛӘП *рәв.* Компания (1 мәгъ.) белән, компания булып. *Компанияләп кәеф ачарга Минзәлинский яратмый бугай.* К. Нәҗми.

КОМПА'НИЯЧЕЛ *с.* Компаниядә булырга ярата торган, компаниягә тиз үзләшүчән.

КОМПАНЬОН *и.* 1. Кемгә дә булса берәр төрле эштә компания тәшкил итүче кеше; иптәш, мәҗлестәш. *Тирече Хәмзә бу хәтәр эштә компаньон булып катнашырга сүз бирде.* Ф. Хөсни. *Агайның кызмача икәнлеген урамда чакта ук сизгән идем. Ул, күрәсең, үзенә компаньон эзләп йөргәндер.* И. Гази.

2. Сәүдә яки промышленность компаниясенең члены. *Гроссман үзенең вексельләрен Пауль исәбгә банкка салды һәм завод хуҗасының компаньоны булды.* Н. Дәүли.

КОМПАНЬОНЛЫК *и.* Компания (1, 2 мәгъ.) члены булу. *Бай үлде.* [*Габдрахманның*] *компаньонлык планнары, бай семья белән туган-тумача булу, йөрешү хыяллары юкка чыкты.* Ә. Фәйзи.

КОМПА'РТИЯ *и.* Коммунистлар партиясе. *Гитлер үз властен мылтык белән терәтеп куйды. Илдә компартия һәм башка партияләр тыелды.* Н. Дәүли.

КО'МПАС *и.* 1. Дөньяның дүрт ягын билгеләү өчен кулланыла торган прибор (һәрвакыт төньякны күрсәтә

торган магнитлы угы бар). *Бер кытай авылы янына барып чыккач кына без, халыктан сорашып һәм компасыбыз белән тикшереп, элекке юнәлешебезне таптык.* А. Шамов.

2. *күч.* Эшчәнлеккә юнәлеш бирүче көч. *Компасым итеп Тезисларыңны, Маягым итеп максатларыма, Киләчәгемне күрергә бардым Җиделлыкның азакларына.* Х. Туфан.

КОМПЕНСА'ТОР *и. тех.* Нинди дә булса механизмнарның эшен тигезләү яки нәрсәнең дә булса аермасын үлчәү өчен билгеләнгән төрле приборлар атамасы.

КОМПЕНСАЦИОН *с.* 1. Компенсациягә (1 мәгъ.) бәйләнешле. *Компенсацион түләүләр.*

2. Компенсация (3 мәгъ.) өчен хезмәт итә торган. *Компенсацион җайланма. Компенсацион маятник.*

КОМПЕНСА'ЦИЯ *и.* 1. *кит.* Кайтару, каплау тәртибендә бирелә торган бәрабәр түләү. *Компенсация талап итү хокукы.* || Өстәмә эш өчен закон нигезендә хезмәт хакыннан тыш түләү. *Файдаланылмаган ял көннәре өчен компенсация алу.* || Шундый очракта түләнә торган акча үзе. *150 сум күләмендә компенсация бирү.*

2. *мед.* Организмда туган көчле авыртуның әкренләп кимүе, элеккеге эзенә төшүе. *Йөрәк авыруы компенсациясе.*

3. *тех.* Төгәл механизмнарның дөрес эшләвенә комачаулый торган тышкы тәэсирләрнең бетү күренеше. *Хронометр компенсациясе.*

КОМПЕНСА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Компенсация ясау. *Компасны компенсацияләү.*

КОМПЕТЕНТЛЫ *с.* 1. Нинди дә булса өлкә, мәсьәлә буенча яхшы хәбәрдар, тирән белемле. — *Мин сине компетентлы медицина белгеченнән каратырга булдым.* Т. Гыйззәт. || Яхшы хәбәрдарлыкка нигезләнгән; төпле, ышандыргыч, авторитетлы. *Компетентлы фикер.*

2. Билгеле бер мәсьәләләр, эшләр буенча тиешле вәкаләткә, хокукка ия булган. [*„Тукай турында зәмандашлары“ дигән*] *китапны яңадан бастырганда бөек шагыйрьнең тормышы һәм иҗат эшчәнлеге турындагы материалларны компетентлы комиссия җитәкчелегендә --- зур игътибар белән карап, төзәтеп чыгарга кирәк.* Каз. утл.

КОМПЕТЕНТЛЫЛЫК *и.* Компетентлы булу.

КОМПЕТЕ'НЦИЯ *и. кит.* 1. Нинди дә булса өлкә, мәсьәлә буенча яхшы хәбәрдарлык, белемлелек. — *Җитәрлек компетенцияләре булмаган хәлдә операция ясаган булып, авыруны вакытыннан элек теге дөньяга озаттылар.* Г. Әпсәләмов.

2. Берәр учреждениенең яки урындагы кешенең нинди дә булса мәсьәләләр буенча эш йөртүгә булган вәкаләте, хокукы. — *Җинаятьчеләрнең эшен тикшерү безнең компетенциягә керми.* М. Хәсәнов.

КОМПЕТЕ'НЦИЯЛЕ *с. к.* компетентлы. — *Менә безнең Альфред Яхич сезне кызыксындырган темада иң компетенцияле кеше.* А. Расих. — *Нәшрият* [*минем хезмәтемә*] *уңай фикердә. Тик компетенцияле рецензент кына таба алмыйлар.* Г. Әпсәләмов.

КОМПИЛЯТИВ *с.* Компиляция юлы белән төзелгән, компиляциягә нигезләнгән. *Компилятив характердагы хезмәт.*

КОМПИЛЯ'ТОР *и. кит.* Компиляция белән шөгыльләнүче.

КОМПИЛЯ'ЦИЯ *и. кит.* 1. Чыганакларны мөстәкыйль эшкәртмичә, башка авторлар тикшеренүләреннән күчереп алып нинди дә булса хезмәт, әсәр язу.

2. Шундый юл белән төзелгән хезмәт; күчермә. [*Кайбер тәнкыйтьчеләр*] *кеше фикерләреннән гыйбарәт булган компиляция белән чыгып, ике ягын да тигез итеп, бер үк вакытта* [*әсәрне*] *мактыйлар да, сүгәләр дә.* А. Шамов.

КОМПИЛЯ'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Компиляция (2 мәгъ.) ясау, компиляция белән шөгыльләнү.

КО'МПЛЕКС *и.* Нинди дә булса предметлар, күренешләр яки үзенчәлекләр җыелмасы. *Аваз комплексы. Гимнастик күнегүләр комплексы. Агротехник чаралар комплексы.*

КО'МПЛЕКСЛАП *рәв.* Комплексы итеп. — *Менә шулай, Арслан туган. Производствода син эшеңне комплекслап алып барасың. Завод салу мәсьәләсен дә комплекслап уйларга кирәк.* Г. Ахунов.

КО'МПЛЕКСЛЫ *с.* Бөтен бер төркем предметларны, күренешләрне яки үзенчәлекләрне әченә алган; нәрсәнең дә булса комплексларыннан торган. *Комплексы анализ. Комплексы фәнни тикшеренү.* □ *Машинаны машина эшли! Менә бит ничек! Комплексы механизация дип атала.* Р. Төхфәтуллин.

Комплексы бригада — төрле тармакта эшләүчеләрдән торган хезмәт-җитештерү бригадасы. *Соңгы елларда ул Югары Тегермәнле авылында комплексы бригада белән җитәкчелек итә.* С. Рафиков.

КОМПЛЕКТ *и.* 1. Билгеле бер максатка хезмәт итә торган нинди дә булса предметларның тулы җыелмасы (инструментлар, әйбер кисәкләре, детальләр һ. б.). *Шикәр чөгендерен игүне тулысынча механикалаштыру өчен совхозга машиналар комплекты кайтару.* □ *Революция һәм гражданнар сугышы елларында чыккан татар матбугаты тулы килеш сакланмаган. --- Ә кайбер газеталарның комплекты бөтенләй юк.* Х. Госман.

2. Инструкция яки штат буенча берәр җиргә кабул ителә, урнаштырыла торган кешеләрнең тулы саны. [*Татар халык мәгариф институтында*] *безне: „Бик алган булыр идек тә, егетләр, комплект тулды шул“, дигән сүзләр белән каршыладылар.* Каз. утл.

КОМПЛЕ'КТЛАҮ *ф.* Комплект төзү, комплектка тутыру, тиешле комплект белән тәэмин итү. *Мәктәпләрне комплектлау. Бәйрәмгә бүләкләр комплектлау. Машиналарны детальләр белән комплектлау. Гарнизонны сугыш кирәк-яраклары белән комплектлау.*

КОМПЛЕ'КТЛАШТЫРУ *ф.* Тиешле комплект белән тәэмин итү. *Мәктәпне укытучылар белән тулысынча комплектлаштыру.*

КОМПЛЕ'КТЛЫ *с.* Комплектлап чыгарылган, эшләнгән. *Комплектлы җиһазлар.* || Саннар янында килеп, „шул сан күрсәткәнчә комплекттан (2 мәгъ.) торган“ мәгънәсен белдерә. *Өч комплектлы башлангыч мәктәп. Уналты комплектлы урта мәктәп.*

КОМПЛЕ'КЦИЯ *и. кит.* Тән төзелеше, гәүдә.

КОМПЛИМЕНТ *и. кит.* Мактау сүзе, мактаулы сүз. *Михаил Хәятка туры гына карап комплиментлар әйтеп китәргә дә онытмый һәм бу эше белән Хәятны кайсы вакыт кызартып та җибәрә иде.* Ф. Әмирхан. *Күнелле гәп башланды. Комплиментлар әйтешеп, гөр килеп көлешеп алдылар.* М. Хәсәнов.

КОМПОЗИ'ТОР *и.* Музыкаль әсәрләр иҗат итүче. *Композиторлар союзы.* □ *Бу әле күптән түгел генә татар композиторларының берсе тарафыннан язылган яңа бию көе иде.* Г. Әпсәләмов.

КОМПОЗИ'ТОРЛЫК *и.* Композитор булу һөнәре. — *Укытучы үземә әйтте:* [*малаегызның*] *композиторлык сәләте бар, диде.* Г. Мөхәммәтшин.

КОМПОЗИЦИОН *с.* Композициягә (1, 3 мәгъ.) бәйләнешле. *Әсәрнең композицион үзенчәлеге.* □ [*Музыканың*] *композицион нигезләрен төпченеп өйрәнү* [*Хәбиргә*] *артык күңелсез һәм эчпошыргыч тоелды, тизрәк үзенең язасы, иҗат итәсе --- килде.* Ш. Хөсәенов.

КОМПОЗИ'ЦИЯ *и. әд.* 1. Әдәбият һәм сәнгать әсәрләренең төзелеше, төп кисәкләренең урнаштырылу

тәртибе. *„Гасырлар һәм минутлар" әсәренең бөтен сюжеты, композициясе, тел, тасвир чаралары — һәммәсе дә антитезага корылган.* Х. Госман. *Г. Нигъмәти, тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме буларак, әсәрнең теле, композициясе һәм сурәтләү чараларына да зур игътибар бирә иде.* И. Нуруллин.

2. Музыкаль әсәр. || Әдәби, музыкаль әсәрләрнең яки аларның кисәкләренең тема, сюжет буенча берләштерелгән тезмәсе. *Әдәби-музыкаль композиция.*

3. Музыкаль әсәрләр төзү теориясе. *Композиция классы.*

КОМПОЗИ'ЦИЯЛЕ *с.* Композициягә нигезләнгән, бер бөтен композиция (1 мәгъ.) тәшкил иткән. *Портретлар, композицияле рәсемнәр, этюдлар инде бу кешеләрнең [рәссамнарның] башларында сирәк-мирәк кенә көмеш укалар күренә башлагач пәйда була.* Н. Дәүли.

КОМПОНЕНТ *и.* Нәрсәнең дә булса состав кисәге, өлеше. *Химик кушылма компонентлары. Фразеологик әйтелмәнең компонентлары.* □ *Һәр синтетик сәнгатьтә теге яки бу компонент өстенлек алып тора. Мәсәлән, операда өстенлек алучы компонентлар — вокаль һәм симфоник музыка, балетта—бию һәм оркестр.* Ж. Фәйзи.

КОМПОСТ *и. а.-х.* Төрле үсемлек ташландыклары, хайван тизәкләре черемәсен торф яки туфракка кушып әзерләнгән органик ашлама. *Тирескә известь кушып әзерләнгән компост.*

КОМПО'СТЕР *и. махс.* Билетка, пломбага һ. б. тишеп яки кысып билге ясау өчен кулланыла торган келәшчә сыман яки башка төрле махсус прибор. *Троллейбусларны компостерлар белән җиһазлау.*

КОМПО'СТИРЛАУ *ф.* Компостер белән билге ясау. *Трамвай билетын компостирлау.*

КОМПОТ *и.* Төрле (гадәттә кипкән) җимешләрне шикәрле суда кайнатып ясалган татлы эчемлек. *Фәхри карчык ашны аз булса да төрләндерә, токмачтан соң бәрәңге белән куырылган ит, актыкта компот яисә кесәл хәзерли иде.* Ш. Камал. || Шушы ашамлык өчен киптереп хәзерләнгән төрле җиләк-җимеш катнашмасы.

КОМПРАДОР *и. кит.* Көнчыгыштагы кайбер колониаль һәм бәйле илләрдә җирле базар белән чит ил капиталы арасында эш йөртүче купец-арадашчы. || Компрадор буржуазия вәкиле.

Компрадор буржуазия — көнчыгыштагы кайбер бәйсез һәм колониаль илләрдә чит ил капиталы белән тыгыз әлемтәдә булган җирле эре буржуазия. *Компрадор буржуазия хакимлеге.*

КОМПРЕСС *и. мед.* Дәвалау, авыртуны киметү максаты белән, суда яки берәр төрле дарулы сыекчада юешләп, авырткан урынга куя торган чүпрәк, бәйләвеч. *Җылыткыч компресс.* □ *Сестра Җамалины кочаклап тотты да тыныч ландырырга кереште һәм башына салкын сулы чүпрәк белән компресс куйды.* М. Гали.

КОМПРЕ'ССИЯ *и. тех.* Двигатель цилиндрындагы басым астында газсыман җисемнең кысылуы, тыгызлануы.

КОМПРЕ'ССОР *и.* **1.** *махс.* Һаваны, парны, газны кысу, тыгызлау машинасы. *Пешкәкле компрессор. Үзәктән кугыч компрессор.* || *с. мәгъ.* Компрессорга бәйләнешле. *Компрессор станциясе.* || *с. мәгъ.* Компрессорлар эшли торган. *Компрессор заводы.*

2. *мед.* Операция вакытында кан тамырын кысып тору өчен кулланыла торган прибор.

КОМПРЕ'ССОРЛЫ *с.* Компрессорлардан торган. *Компрессорлы җайланмалар.*

КОМПРОМИСС *и. кит.* Үзара ташламалар ясау юлы белән ирешелгән килешү. *Компромисска бару.* || *с. мәгъ. к.* компромисслы. *Мәсьәләне компромисс юл белән хәл итү.*

КОМПРОМИССЛЫ *с.* Үзара ташламалар ясый торган. *Компромисслы тәкъдим.*

КОМПРОМИССЫЗ *с.* Компромисска нигезләнмәгән; ташламасыз. *Бәһавиның хәзерге яшәү максатын һәм чараларын компромиссыз тәнкыйтьләү белән бергә, А. Расих аның яшьрәк чакта намуслы кеше булуын да искә ала.* Каз. утл.

КОМСОМОЛ *и.* **1.** Коммунистик яшьләр союзы. *Комсомолга керү.* □ *Комсомол — кайчан гына булмасын, кайда гына булмасын — партиянең иң якын ярдәмчесе.* М. Әмир.

2. Коммунистик яшьләр союзы члены; комсомолец, комсомолка. *Комсомоллар — яшь ленинчылар алар. Комсомоллар — Искелеккә бомбалар!!* Һ. Такташ. || *с. мәгъ.* Комсомолларны берләштергән, комсомоллардан торган. *Комсомол оешмасы. Комсомол рейды группалары.*

КОМСОМО'ЛЕЦ *и.* Коммунистик яшьләр союзы члены. *Комсомолец — бөек исем, Тик эш белән.* М. Җәлил.

КОМСОМО'ЛИЯ *җый. и. кит.* Комсомоллар, комсомол яшьләр. *Илне электрлау, Комсомолия, Безнең эшебез!* Ф. Кәрим.

КОМСОМО'ЛКА *и.* Хатын-кыз комсомол. [*Наилә:*] *Мин комсомолка, партия сафына керергә хәзерләнәм.* Р. Ишморат.

КОМСОМОЛЛА'РЧА *рәв.* Комсомолларга хас булганча. *Комсомолларча дәртләнеп эшләү.*

КОМСОМОЛЛЫК *и.* Комсомол члены булу. *Рух төшерсәк, безнең комсомоллык Исемебездән нәрсә кала соң?* М. Җәлил. *Күптәнме әле алганда Комсомоллык билетын Сүз бирдең син кызартмаска Комсомолларның битен.* Ә. Исхак.

КОМСОРГ *и.* Комсомол члены булган яшьләрне оештыручы (башлангыч комсомол оешмасының яки комсомол группасының җитәкчесе). *Гөлчирә цех комсоргы Саша Уваров, аннары парторг Сидорин белән сөйләште дә комитетка чапты.* Г. Әпсәләмов.

КОМСОСТАВ *и.* Командирлар составы. *Крепость йокыга чума. Комсостав йортларында да утлар берәм-берәм сүнә баралар.* Э. Касыймов.

КОМСУ *с.* Ком катнашкан, составында беркадәр комы булган. *Монда комсу җир түгел.* М. Гафури.

КОМСЫЗ *с.* **1.** Үз файдасы өчен генә тырышучы, үтә саран; ач күзле, туемсыз. *Комсыз кешенең корсагы бервакытта да тулы булмый.* Г. Кутуй. Комсыз котырса, коега кармак салыр. Мәкаль. || Канәгатьләнүне белми торган. *Илебезне җимерер, талар өчен, Комсыз байлар, лордлар, түрәләр Бүген анда, канлы Европада, Тәре үбеп антлар бирәләр.* Һ. Такташ. *Бабай саранлыкны, ач күзле, комсыз булуны бер дә яратмый иде.* Г. Гали.

2. *күч.* Нәрсәгә дә булса чиктән тыш зур теләге, омтылышы, ихтыяҗы булган; хирыс. *Тормышка комсыз булган бу кыз сугышка да комсыз була.* И. Гази. || Шундый теләк, ихтыяҗ белдерә торган (күз, йөз, караш турында). *Зәһәрләнеп янган менә бу комсыз күзләр [Тимерине] айнытып җибәрде.* Г. Бәширов.

КОМСЫЗЛАНУ *ф.* **1.** Комсызлык күрсәтү. — [*Хәкимнәр*], *шул яңа эшләренең тәмен белеп алгач, бигрәк комсызланып киттеләр.* М. Фәйзи. — *Кеше, акчага, юк-бар нәрсәгә комсызланып, үзенең алтыннан кадерле булган тормышына, дөньяда яшәү хокукына хыянәт эшләсен имеш.* Т. Гыйззәт.

2. *рәв. мәгъ.* **комсызланып.** Комсызлык (1 мәгъ.) белән. *Илморза комсызланып ашый башлады.* Г. Әпсәләмов. *Барыбыз да комсызланып, ашыга-ашыга [җиләк] җыярга керештек.* М. Гали. || *күч.* Киеренке

игътибар белән, бик нык мавыгып, кызыксынып, түземсезләнеп. *Мин аларның хәрәкәтләрен күзәтергә, сүзләрен комсызланып тыңларга керештем.* А. Шамов. *Фазыл - - - комсызланып очеркны укый башлады.* Г. Гобәй.

КОМСЫЗЛЫК *и.* 1. Комсыз (1 мәгъ.) кешегә хас сыйфатлар. *Байлар һаман комсызлыктан туймый иде, Акча артыннан чабуын куймый иде.* Г. Камал. *Комсызлык һәр җирдә гаеп, белемгә комсызлык гаеп түгел.* Мәкаль.

2. Комсыз (2 мәгъ.) булу халәте, хирыслык. — *Хыял сездә ижат омтылышы, ижат комсызлыгы тудырыр.* Г. Бәширов. *Каюм укырга тәкъдим иткән китапларны да [Хәйбулла] комсызлык белән укый.* Ш. Камал.

КОМСЫЛ *с. к.* комсу. *Комсыл туфрак.*

КОМТАШ *и.* Кызыл балчык һәм ком катнашмасыннан торган утырма тау токымы. *Өстәлдә җир астының төрле тирәнлекләреннән алынган токым үрнәкләре: комташ, - - - доломит, нефть катлавы кернары ята.* Каз. утл.

КОМФОРТ *и. кит.* Көнкүреш ихтыяҗлары өчен тудырылган уңайлыклар. *Бу [гостиницада] кешенең җаны теләгән комфорт бар.* Сов. әд. *Тукай Астраханьнан Казанга кайту билетын кулына алып карауга кашларын җыерды. — Беренче класс. — дйе. Комфортта кайт әле бер.* Г. Минский.

КОМФОРТА'БЕЛЬЛЕ *с.* Комфорты булган, көнкүреш һ. б. өчен уңайлы. *Комфортабельле кунак йорты. Комфортабельле автобус.*

КОМФОРТА'БЕЛЬЛЕК *и.* Комфортабельле булу. *Яңа тимер юл вокзалының комфортабельлеге.*

КОМФОРТЛЫ *с. сөйл. к.* комфортабельле. *Блиндаж эче чиста, җыйнак һәм фронт шартлары өчен шактый комфортлы.* И. Гази.

КОМЫК *и.* Дагстан АССРда яшәүче төрки халыкларның берсе; шул милләт кешесе.

КОМЫ'КЧА *рәв.* Комык телендә.

КОМЫРЫК *и.* 1. *иск.* Тын урам, аулак тыкрык.

2. *диал.* Елганың агым көчле булмаган тирән урыны. *[Малайлар], комырыклардан вак чабакларны, этлиләрне пыркытып чыгарып, балык сөзәләр.* А. Гыйләҗев. *Бака да әйтер имеш: ятыр җирем, умырыгым, комырыгым.* Әйтем.

КОН *и.* 1. Кузна, чүрәкәй һ. б. ш. уеннарда аткый яки сага барып төшәргә тиеш сызык.

2. Отышлы уенда акча яки башка әйбер салына торган билгеле бер урын. *Зурлары [карта уйныйлар]. - - - Һәркайсының шырпы тартмасында, коннарында [кырыена дегет сыланган калай банкада] кызыл таракан.* Г. Гобәй. || Шул урынга уен барышында җыелган акча. *Карта уйнаштыргалыйм. Этлекне дә белә башладым. Күз ачып йомганчы бер картаны икенче карта белән алыштырып куям. Күрсәләр — ипи шүрлегенә әләгә, күрмәсәләр — бөтен кон минеке.* Ф. Хөсни.

3. Карта, шахмат һ. б. ш. уеннарның бер партиясе.

КОН [қон] *и. иск.* Кыяфәт, төс; күрек, ямь (кешегә карата). *Адәм дисәң — коны юк, хайван дисәң — йоны юк.* Мәкаль. *Қолда кон булмас, йөгерек атта сын булмас.* Мәкаль.

КОНАР [қонар] *и. диал. к.* кон [қон]. *Конары юк.*

КОНАРСЫЗ *с.* Ямьсез, килешсез. *Эшсез яшьнең йөргәне конарсыз, Эттән башканың өргәне конарсыз.* Мәкаль. — *Хисаметдиннең кызын күрдем, бигрәк конарсыз нәрсә икән: үзе озын, үзе чыра шикелле, шадра, авызы кыек, чепи күзле, кәкре аяклы.* Г. Камал.

КОНВЕ'ЙЕР *и.* Өзлексез хәрәкәт итеп, эшкәртелә торган әйберләрне бер операциядән икенче операциягә яки йөкләрне бер урыннан икенче урынга күчергеч җайланма. *Тасмалы конвейер. Асылма конвейер.* □ *Беренче конвертка салынган эчлек-мамык белән марля озын конвейер буйлап барган саен бөтенәя, бүрек кыяфәтенә керә.* М. Максуд. *Пилорама цехында эш конвейерга куелган.* М. Хәсәнов. || *с. мәгъ.* Конвейерга бәйләнешле. *Конвейер методы. Конвейер системасы.*

Конвейер белән — берсе артыннан берсе; тоткарсыз, өзлексез. *Алтышар ат җиккән авыр туплар өзлексез конвейер белән шәһәрдән вокзалга агылды.* Ш. Усманов.

КОНВЕ'ЙЕРЛАШТЫРУ *ф.* Конвейер белән эшләүгә күчү, конвейер системасына күчерү.

КОНВЕ'ЙЕРЧЫ *и.* Конвейерны эшләтүче.

КОНВЕ'КЦИЯ *и.* 1. *физ.* Җылылык яки электр корылмаларының хәрәкәтчел мохит ярдәмендә күчерелүе. *Конвекция агымы.*

2. *махс.* Диңгезләрдә, океаннарда суның тыгызлыгы, тозлылыгы һәм температурасы үзгәрүгә бәйләнешле рәвештә, югарыгы катлам белән түбәнге катлам арасында су алмашу күренеше.

3. *махс.* Атмосфераның тигез җылынмавы аркасында югарыгы катлам белән түбәнге катлам арасында бара торган һава алмашыну күренеше.

КОНВЕНТ *и. тар.* Кайбер илләрдә махсус закон чыгару хокукы (вәкаләте) белән сайлап куела торган орган. *Милли конвент.*

КОНВЕНЦИОН *с.* Конвенциягә бәйләнешле. *Конвенцион тариф.*

КОНВЕ'НЦИЯ *и. махс.* Дәүләтләр арасында нинди дә булса махсус мәсьәлә буенча төзелгән килешү, договор. *Консуллык конвенциясе. Тимер юл конвенциясе.* □ *Барлык халыкара конвенцияләр буенча да хәрби әсирләрне үз ватандашларына һәм союздашларына каршы сугышу өчен корал һәм сугыш техникасы эшләп чыгарырга мәҗбүр итү катгый рәвештә тыела.* Каз. утл.

КОНВЕРГЕ'НЦИЯ *и.* 1. *махс.* Бер-беренә бәйле булмаган төрле күренешләрнең аерым сыйфатлар ягыннан үзара охшашлыгы.

2. *биол.* Төрле организмнарда кардәшлек нәтиҗәсе буларак түгел, бәлки бердәй шартларда яшәүгә җайлашу сәбәпле барлыкка килгән кайбер тышкы яки эчке төзелеш охшашлыгы.

КОНВЕРСИОН *с. экон. к.* конверсияле.

КОНВЕ'РСИЯ *и.* 1. *экон.* Дәүләт заемы шартларының үзгәртелүе (мәсәлән, проценты киметелү, түләү вакыты озайтылу). *Заем конверсиясе.*

2. *лингв.* Сүзнең нигезен яки аның формасын бер сүз төркеменнән икенче сүз төркеменә күчерү юлы белән яңа сүз ясау күренеше (мәсәлән: зур *хата* — *хата* фикер, *сәбәпле* бәйләнеш — авыру *сәбәпле*, бөтен *көчкә* чабу — *көчкә* барып җитү һ. б.).

КОНВЕ'РСИЯЛЕ *с. экон.* Конверсия ясалган. *Конверсияле заем.*

КОНВЕ'РСИЯЛӘҮ *ф. экон.* Конверсия ясау.

КОНВЕРТ *и.* 1. Хат, документ һ. б. ш. нәрсәләр салу өчен кәгазьдән гадәттә дүрт почмаклап эшләнгәт пакет. *Хатны язып бетерде дә Салды кызыл конверт эченә.* М. Җәлил.

2. Күкрәк баласын төрү өчен пакет формасында тегелгән одеялның бер төре.

КОНВЕРТЛАУ *ф.* Нәрсәне дә булса конверт (1 мәгъ.) эченә салып ябыштырып кую. *Давыт - - - хатны конвертлады да кесәсенә тыкты.* Г. Ибраһимов.

КОНВЕРТЛЫ *с.* Конвертка салынган, конвертланган. *[Габсаттар] кесәсеннән конвертлы хат чыгара.* Г. Камал.

КОНВОИР *и.* 1. *к.* конвойчы. *Ул арада конвоирларның башлыклары килеп, Гыйльманов белән Егорычны чанага утыртты.* М. Гали. *Йөзләгән әсирне берничә немец конвоиры озатып йөри.* Ш. Маннур.

2. Аерым кораблне, суднолар төркемен озатып бара торган сакчы судно яки самолет.

КОНВОИРЛЫК *и.* Конвоир хезмәте. *Ун солдатны конвоирлыкка билгеләү.*

Конвоирлык итү — конвоир вазифасын үтәү. [*Әсирләргә*] *ике сугышчы конвоирлык итә.* Х. Госман.

КОНВОЙ *и.* 1. Тоткыннарны, әсирләрне һ. б. саклап озатучы кешеләр төркеме, кораллы отряд. [*Әсирләр*] *автоматлар белән коралланган явыз конвой чолганышында иде.* А. Расих.

2. Сәүдә, транспорт судноларын юлда дошманнан саклап бара торган кораблләр яки самолетлар.

КОНВОЙЛЫ *с.* Конвой сагы астында булган, конвой белән алып барыла торган. *Яңгырлы төндә, Двинск шәһәре вокзалында, конвойлы дусларның юлы икегә аерылды.* Ш. Маннур.

КОНВОЙЧЫ *и.* Тоткыннарны, әсирләрне һ. б. саклап алып баручы, озатучы кеше. *Верещагин, - - - кайсын башы белән төртеп, кайсын аягы белән тибеп, конвойчыларны бәреп екты.* Г. Әпсәләмов.

КОНВУЛЬСИВ *с.* Конвульсиягә бәйләнешле. *Кулларның конвульсив хәрәкәтләре.*

КОНВУ'ЛЬСИЯ *и.* 1. *кит.* Көзән җыеру.

2. *күч.* Ярсулы, куркынычлы хәл; көчле чуалыш. [*Губернатор:*] *Хәзер инде беренче конвульсияне әкренләп суытырга,* [*революцион хәрәкәтнең*] *башлыкларын сиздермичә генә эләктерергә.* К. Нәҗми.

КОНГЛОМЕРАТ *и.* 1. *кит.* Төрле кисәкләрнең һәм әйберләрнең механик һәм очраклы, тәртипсез кушылмасы.

2. *геол.* Кызыл балчык, тимер ачылыгы һ. б. ш. катнашмасында укмашкан чуерташлы, эре йомры ташлы утырма тау токымы. *Пермь утырма токымнарыннан мергель, балчык, комташ һәм конгломерат та зур байлыклардан саналалар.* Җир һәм туфрак.

КОНГРЕСС *и.* 1. Гадәттә халыкара әһәмиятле мәсьәләләр буенча үткәрелә торган съезд, киң күләмле җыелыш. *Халыкара хатын-кызлар конгрессы.* □ *Президиумда негр Норрис та бар, Ул утырды килеп иң алга: Профинтерн конгрессыннан Вәкил булып килгән Уралга.* Ф. Кәрим.

2. АКШта, Латин Америкасы илләренең күпчелегендә закон чыгару органының (парламентның) атамасы.

КОНГРЕССМЕН *и.* Конгресс (2 мәгъ.) члены. [*Капитолийда*] *сенат, вәкилләр палатасы утырыш үткәрә, конгрессменнар, сенаторлар җыела.* Каз. утл.

КОНДЕНСАТ *и. хим.* Саркым, саркытма, утырма, куерма. *Су парлары конденсаты.*

КОНДЕНСА'ТОР *и. физ., тех.* 1. Электр энергиясе туплау приборы. *Яссы конденсатор.* □ *Марс физика дәреслеген конденсаторга* [*алмаштырган*]. А. Тимергалин.

2. Файдаланылган парны суытып суга әйләндерә торган прибор. *Каршыда гигант конденсаторлар белән суыткычлар* [*күренә*]. М. Хәсәнов.

КОНДЕНСАЦИОН *с. махс.* Конденсация өчен билгеләнгән. *Конденсацион җайланма.* || Конденсацияләү юлы белән алынган. *Конденсацион су.*

КОНДЕНСА'ЦИЯ *и. махс.* 1. Тупланыш, куелык, тыгызлык. *Электр конденсациясе.*

2. Парның яки газның куерып тыгызлануы, сыек хәлгә килүе. [*Мотор эшләгәндә*] *газга куе кушылма бирергә ярамый, - - - конденсация була.* Х. Госман.

КОНДЕНСА'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* 1. Туплау, куерту, тыгызлау. *Энергияне конденсацияләү.*

2. Парны яки газны сыек хәлгә китерү.

КОНДИ'ТЕР *и.* 1. Татлы ашамлыклар хәзерләү остасы. || *с. мәгъ.* Кондитер әйберләре хәзерләүгә яки шулар белән сату итүгә караган. *Кондитер фабрикасы. Кондитер магазины.*

2. *иск.* Кондитер әйберләре магазинының хуҗасы.

Кондитер әйберләре — конфет, пирожный, торт һ. б. ш. татлы ашамлыклар. [*Пляжда*] *берничә урында сәүдә павильоны бар. Минераль һәм газлы су, - - - кондитер әйберләр белән сату итәләр.* Каз. утл.

КОНДИ'ТЕРЧЫ *и. к.* кондитер.

КОНДИЦИОН *с. к.* кондицияле. — *Орлыгыгыз кондицион түгел. Тишелү проценты җитми.* М. Әмир.

КОНДИ'ЦИЯ *и. махс.* Теге яки бу товарда, материалда, чәчү орлыкларында һ. б. булырга, табылырга тиешле сыйфат, микъдар нормалары. *Агроном, бөтен сәләтен җигеп, орлыкны чәчү кондициясенә җиткерергә тырыша.* Г. Бәширов.

КОНДИ'ЦИЯЛЕ *с. махс.* Билгеле бер таләпләргә, күрсәтелгән стандартка җавап бирерлек; кондициягә җиткерелгән. — *Бодай нигә тишелмәде соң? Сайлап салган шикелле, әйбәт, эре, кондицияле бодай иде бит ул.* Г. Гобәй.

КОНДИ'ЦИЯЛЕЛЕК *и. махс.* Кондицияле булу сыйфаты. *Чәчү орлыкларының кондициялелеген тикшерү.*

КОНДИ'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Куелган нормалар нигезендә төрле продуктларның, материалларның үзлеген, сыйфатын билгеләү, сынау. || Сыйфатын яхшырту максаты белән өстәмә эшкәртү, тиешле кондициягә җиткерү. *Һава кондицияләү җайланмалары.*

КО'НДОР *и. зоол.* Грифлар отрядыннан үләксә белән туена торган, башы һәм муены шәрә зур ерткыч кош. [*Һавада*] *самолетка һөҗүм иткән кош - - - аеруча ерткыч кондор булган.* Соц. Тат.

КОНДУ'КТОР *и.* 1. Поезднын дөрес һәм хәвефсез хәрәкәт итүен, аңардагы йөкнең сакланышын күзәтеп баручы тимер юл хезмәткәре. — *Әфәнде, әчкә керегез, поезд кузгала хәзер, — диде кондуктор.* Ш. Камал. || Шәһәр транспортында — трамвайларда, автобусларда, троллейбусларда билет сатучы, тәртип күзәтүче хезмәткәр.

2. *махс.* Станокларда инструмент белән эшкәртелә торган материал арасында үзара дөрес торышны тәэмин итә торган махсус җайланма. — *Бөраулауны өч йөз егерме метрга җиткердек, әлерәк кенә кондуктор төшерә башладык.* Г. Ахунов.

КОНДУ'КТОРЛЫК *и.* Кондуктор (1 мәгъ.) хезмәте. *Кондукторлыкта эшләү.*

КОНДЫЗ *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан коңгырт сары төстәге кыйммәтле мех бирә торган җирсу җәнлеге. *Дәрәмәдә карама, карамада кондыз бар.* Җыр. *Йолдыз саны артса, Күкнең яме артыр: Кондыз саны артса, Күлнең даны артыр.* М. Җәлил. || Шул җәнлекнең мехы. *Яхшы кыз — якадагы кондыз, Яхшы егет — һавадагы йолдыз.* Мәкаль. || *с. мәгъ.* Шул җәнлекнең мехыннан тегелгән. *Габденнасыйр - - - ике улына да пардан җәен дә, кышын да кия торган кондыз бүрек - - - алдырды.* М. Гали.

КОНДЫЗЛЫ *с.* Кондыз үрчи торган, кондызга бай. *Кондызлы күл.*

КОНДЫРАК *и. бот. диал. к.* кындырак. *Тәкәрлек мөгезен бик дәһшәтле тырпайтып куйды да, йомшак кондырак арасына бер күмелеп, бер калкып, җәйләүгә таба чапты.* Г. Мөхәммәтшин.

КОНДЫРЛЫ: кондырлы кодача (кодагый) — үзенә аерым мөгамәлә, илтифат күрсәтүне таләп итә торган, иркәләнергә ярата торган кешегә карата әйтелә.

[*Нурый Локманга:*] *Эшлә, кондырлы кодача булып утырма.* К. Нәҗми.

КО'НКА *и. иск.* Атлы трамвай (шундый трамвай йөри торган шәһәр тимер юлы; шул юлда йөри торган вагон). *Зур шәһәрләрдә трамвай күреп өйрәнгән күзгә бу конка бик - - - көлке тоела иде.* Г. Тукай. *Конкалар да йөрми, күрәсең, извозчиклар да көзге яңгырдан шүрләп калганнар.* А. Расих.

КОНКЛАВ *и. кит.* Яңа Рим папасын сайлау өчен үткәрелә торган кардиналлар җыелышы; шул җыелыш үткәрелә торган зал.

КОНКРЕТ *с.* Аныk, ачык, төгәл; реаль булган; *киресе:* абстракт. *Конкрет йөкләмә. Конкрет җавап.* □ *Исәбе аныңдан, үзенчә, ферманың хәлен яхшырту өчен конкрет чаралардан торган зур бер программа төзү иде.* Ә. Еники. — *Конкрет эш кешесе мин. Алдымда торган эшне эшләргә яратам.* Р. Ишморат. || *и. мәгъ.* Конкретлык, конкрет форма. *Кави Нәҗми тасвирларында бер төп характерлы сыйфат — аның сурәтләре абстракттан конкретка таба күчерелеп баруында.* Г. Нигъмәти. || *рәв. мәгъ.* Ачык итеп, аныk итеп. [*Җыелышта*] *иртәгә чәчүгә чыгу һәм эш бүлешү мәсьәләләре конкрет тикшерелде.* Ш. Камал. *Сәхнәдә - - - хәрәкәт аша конкрет күрсәтелгән конфликт бик тиз киеренке атмосфера тудыра.* М. Җәлил.

◇ **Конкрет алганда** *кер. сүз* — ачык итеп әйткәндә; мисал, факт, дәлил белән күрсәткәндә.

КОНКРЕТЛАШТЫРУ *ф.* Аныклау, ачыклау, конкретлык кертү. — *Ул теория артык гомуми, аны конкретлаштырырга, практикада кулланырлык дәрәҗәдә конкретлаштырырга кирәк.* А. Расих. [*Артистның*] *мимика һәм тавыш үзгәреше дә образның эчке тормышын ачуга, аның характерын конкретлаштыруга юнәлтелә.* Сов. әд.

КОНКРЕТЛАШУ *ф.* Аныклану, ачыклану, конкретлык керү. *Шигырьләрдәге фикерләр, образлар, детальләр, алымнар торган саен конкретлаша бара.* Р. Харисов.

КОНКРЕТЛЫК, КОНКРЕТЛЫЛЫК *и.* Конкрет булу. *Өйләнешүнең бөтен ягы нигә бүген үк (либреттоның шушы күренешендә үк) бөтен конкретлыгы белән хәл ителергә тиеш?* М. Җәлил. *Артык конкретлылыкка, төгәллеккә омтылуның да кайвакытта - - - кире яклары була.* Н. Юзиев.

КОНКУ́РЕНТ *и.* 1. Кем белән дә булса конкуренция алып баручы; ярышучы, көндәш. [*Габдуллаҗан:*] *Алай куркыныч лы конкурентлар күренми әле.* К. Тинчурин.

2. *иск.* Конкурста катнашучы.

КОНКУРЕНТЛЫК *и.* Конкуренциягә каршы торучылык. *Товарларның конкурентлык сәләте.*

КОНКУРЕ'НЦИЯ *и.* 1. Нинди дә булса бер өлкәдә өстенлеккә, яхшырак нәтиҗәләргә ирешү өчен ярыш, көрәш. *Парламентларга сайлауларда партияләр арасындагы конкуренция.*

2. Товарлыклы җитештерү процессында шәхси җитештерүчеләрнең товарларны файдалырак шартларда җитештерү һәм сату өчен үзара көрәше; капитализм чорында капиталистлар һәм капиталистик илләр арасында табышның зур өлеше өчен бара торган көрәш. *Европа базарларында чыдый алмаслык конкуренция.* Урал. *Иске заманда һәр мастер, һәр хуҗа, берәр яңа нәрсә табылса, башкаларга белдермәскә тырыша. - - - Чөнки конкуренциядән курыкканнар.* Г. Әпсәләмов.

Конкуренция алып бару — ярышу; көндәш булу, конкуренциядә катнашу.

КО'НКУРС *и.* 1. Үзендә катнашучылар арасыннан иң лаеклысын билгеләргә, сайлап алырга мөмкинлек бирә торган ярыш. *Конкурс игълан итү. Конкурстан үтмәү.* □ *Геология факультетына конкурс зур булмый.* Э. Касыймов. *СССР Фәннәр академиясе конкурсында бу яшь архитекторның проектлары икенче урынны алган.* Г. Кутуй.

2. Революциягә кадәрге Россиядә һәм капиталистик илләрдә: күп бурычка кереп бөлгән кешенең эшен карар өчен кредиторлар тарафыннан оештырылган җыелыш.

КО'НКУРСЛЫ *с.* Конкурс белән үткәрелә торган. *Конкурслы имтихан.*

КОНОВАЛ *и. сөйл.* Атлар дәвалау белән шөгыльләнүче, махсус ветеринар белеме булмаган кеше. [*Хәйретдин карт җирән бияне*] *Әйзәдулла исемле мишәр коновалыннан бик зур өметләр белән дәвалатты.* Ш. Камал. || *иск.* Ат печүче.

КОНСЕРВ, КОНСЕ'РВА *и.* Черүдән, бозылудан саклау өчен герметик ябылулы банкаларга махсус эшкәртеп (тозлап, стерилизацияләп) тутырылган ашамлык. *Балык консервасы. Яшелчә консервлары.* □ *Өстәл өстендә ачылган консервлар, - - - колбаса кисәкләре белән аралашкан алмалар, виноградлар сибелеп ята.* А. Шамов. *Хәйдәр кызган консервны уттан алып уртага куйды.* Ш. Усманов.

КОНСЕРВАТИВ *с.* 1. Искелекне яклаучы, яңалыкка, прогресска каршы (политик тормышта, әдәбиятта, фәндә һ. б.). *Консерватив карашлы кеше.* □ *Патша самодержавиесенең яклавы астында консерватив руханилар, карагруһ буржуазия һәм алпавытлар халык арасыннан чыккан җыр-музыка талантларына каршы ерткычларча көрәштеләр.* М. Җәлил.

2. *биол.* Тотрыклы. *Нәселдәнлек үзгәрүгә җиңел бирелми, ул шактый тотрыклы (консерватив) була.* Биология.

Консерватив партияләр — буржуаз реакцион политик партияләр. **Консерватив дәвалау** — операциягә бәйләнмәгән методлар белән дәвалау.

КОНСЕРВАТИВЛЫК *и.* 1. Иске карашлылык, яңалыкка, прогресска каршы булучанлык. *Карашларның консервативлыгы.* □ *Әмма син каерылдың, ясадың Консервативлыкка тайпылыш.* Ә. Фәйзи.

2. *биол.* Тотрыклылык. *Нәселдәнлекнең консервативлыгы.*

КОНСЕРВАТИЗМ *и.* Консервативлык, консерватив карашлар. *М. Гафури - - - иҗатында өченче бер характерлы мотив — наданлыкка, искелеккә - - - һәм консерватизмга каршы көрәш мотивы булды.* М. Җәлил.

КОНСЕРВА'ТОР *и.* 1. Консерватив карашлы кеше. *Гаяз тагын дәвам итте: — Син надан гына түгел, син консерватор, син мещан.* М. Әмир. — *Бураков күп еллар буе колхоз башында торган кеше. Заманында без аңа ихтирам белән карадык. Күрәсез, хәзер ул консерваторга әйләнгән.* С. Рафиков. || *с. мәгъ. к.* консерватив. *Консерватор җитәкче.* □ *Акылың белән болай аңлыйсың күк, Консерватор була хисләрең.* Х. Камалов.

2. Англиядә: реакцион консерватив политик партиянең члены. *Власть консерватор буржуалар кулында.* Г. Гали.

КОНСЕРВАТО'РИЯ *и.* Югары музыка мәктәбе. [*Нәҗия:*] *Минем, консерватория бетереп, җырчы булу өметем - - - төштәй генә булып калдылармыни?* Т. Гыйззәт.

КОНСЕРВА'ЦИЯ *и. кит.* 1. Махсус эшкәртү, махсус шартлар тудыру юлы белән черүдән, бозылудан саклап алып калу.

2. Нәрсәнең дә булса үсешен, хәрәкәтен, эшен вакытлыча туктатып тору хәле. [*А. Фадеев*] *Җәлил ки-*

табын чыгару буенча ашыгыч чаралар күру, консервациядән алу кирәклеге турында сөйли. Н. Юзиев.

КОНСЕРВА'ЦИЯЛӘУ *ф. кит.* Консервация (2 мәгъ.) ясау. [*Ректор:*] *Кемнеңдер нәрсәдер әйтүеннән куркып, без кафедраны консервацияли алмыйбыз.* А. Расих.

КОНСЕ'РВЛАУ *ф.* Консерв ясау, консерв итеп әзерләү. *Җиләк-җимешләр консервлау. Консервланган балыклар.*

КОНСИ'ЛИУМ *и. мед.* Кыен очракларда авыруның чирен һәм аны дәвалау юлларын билгеләү өчен үткәрелә торган врачлар киңәшмәсе. *Самуил Абрамович - - - профессор Таһировны үз клиникасына консилиумда катнашырга чакырды.* Г. Әпсәләмов.

КОНСОЛИДА'ЦИЯ *и. кит., махс.* Консолидацияләү эше. *Милләтләр консолидациясе. Заемнар консолидациясе.*

КОНСОЛИДА'ЦИЯЛӘУ *ф.* **1.** *кит.* Бергә туплау, ныгыту. *Иҗтимагый көчләрне консолидацияләү.*

2. *махс.* Дәүләтнең кыска сроклы бурыч йөкләмәләрен озын сроклыга әйләндерү.

КОНСОНАНС *и.* **1.** *муз.* Берничә авазның үзара ярашып яңгыравы, аһәңлелеге; *киресе:* диссонанс.

2. *әд.* Тулы булмаган рифманың бер төре: рифмалашучы сүзләрдә бары тик тартык авазлар гына аваздаш булалар һәм кабатланалар.

КОНСОНАНТИЗМ *и. лингв.* Нинди дә булса бер телнең тартык авазлар системасы.

КОНСО'РЦИУМ *и. экон.* Эре банкларның, банкирларның зур финанс операцияләрен (заем яки акцияләр тарату һ. б.) бергәләп башкару өчен төзегән монополистик берләшмәсе.

КОНСПЕКТ *и.* Нәрсәнең дә булса кыскача язма әүтәлеге. *Лекцияләр конспекты.* □ *Каюм үзенең конспекты буенча әлеге томанлыклар һәм аларның төрле хикмәтләре турында сөйләп китте.* Ш. Камал. *Солтан кичә хәзерләнгән дәрес конспектын тагын бер кат күздән кичерергә кереште.* Г. Кутуй.

КОНСПЕКТИВ *с.* Конспект характерындагы, кыска, җыйнак.

Конспектив рәвештә — кыска гына итеп.

КОНСПЕКТИВЛЫК *и.* Кыскалык, җыйнаклык.

КОНСПЕ'КТЛАШТЫРУ *ф.* Конспектлап чыгу (нәрсәне дә булса).

КОНСПЕ'КТЛАУ *ф.* Конспект төзү. *Лекцияләрне конспектлау.* □ *Бу китапны укып чыгу һәм кирәк урыннарын конспектлау шактый күп вакыт сорый.* Г. Әпсәләмов.

КОНСПИРАТИВ *с.* Конспирациягә бәйләнешле; яшерен, яшертен. *Конспиратив киңәшмә.* □ [*Фәхри бүлмәсе*] *хәзер революциянең конспиратив квартираларыннан берсе була.* Г. Ибраһимов. *Съездның тулы карарлары кулга килеп кермәсә дә, анда каралган мәсьәләләр Надежда Константиновна Крупскаяның конспиратив хаты буенча билгеле иде инде.* А. Расих.

КОНСПИРА'ТОР *и.* Конспирация методы белән эш итүче. *Көчле агитатор һәм оста конспиратор Муса - - - кыен шартларда да дошманга каршы аяусыз көрәшче була.* Г. Иделле.

КОНСПИРА'ТОРЛЫК *и.* Конспиратор булу. *Конспираторлык тәҗрибәсе.*

КОНСПИРА'ЦИЯ *и.* Легаль булмаган оешма тарафыннан үзенең эшчәнлеген һәм членнарын яшерүдә кулланыла торган методлар; серне бик нык саклау. — *Конспирация — иң кирәге. Чөнки без [дошманның], урт тешгә басып, бугазына ут салабыз. Ул шуны сизми дә калсын.* Ш. Маннур.

КОНСТАНТ *с. махс.* Даими, үзгәрми торган, тотрыклы. *Константлар формалар.*

КОНСТА'НТА *и. махс.* Математика, физика һәм химиядә — даими зурлык. *Сыгылмалылык константасы.*

КОНСТАНТЛЫК *и. махс.* Даимилек, үзгәрмәүчәнлек, тотрыклылык.

КОНСТАТА'ЦИЯ *и. кит.* Нәрсәнең дә булса барлыгын аныклау, билгеләп үтү эше. [*Хезмәттә*] *күренекле прозаиклар, шагыйрьләр - - - иҗатының әһәмияте билгеләп үтелсә дә, бу эш, ничектер, артык тыйнак, констатация һәм гомуми характеристикалар рәвешендәрәк эшләнгән.* Каз. утл.

КОНСТАТА'ЦИЯЛӘУ *ф. кит.* Констатация ясау; барлап, билгеләп, әйтеп үтү. *Безнең авторлар, татар поэзиясенә, проза һәм драматургиягә милли классик традицияләрнең зур йогынтысын констатацияләү белән берәттән, рус әдәбиятының уңай ролен күрсәтүгә зур игътибар биргәннәр.* А. Сайганов.

КОНСТИТУТИВ *с. кит.* Нәрсәнең дә булса нигезен тәшкил итә, билгели торган. *Конституутив үзенчәлекләр.*

КОНСТИТУЦИОН *с.* Конституциягә бәйләнешле. *Конституцион закон.* || Конституциягә нигезләнгән. *Конституцион идарә итү формасы.*

Конституцион монархия — монарх власте конституция белән чикләнгән дәүләт төзелеше.

КОНСТИТУЦИОНАЛИЗМ *и. полит.* Конституцион монархияне иң яхшы идарә итү системасы дип таный торган буржуаз реакцион агым.

КОНСТИТУЦИОНАЛИСТ *и. полит.* Конституционализм тарафдары.

КОНСТИТУ'ЦИЯ *и.* Дәүләтнең төп законы. *СССР Конституциясе.*

КОНСТИТУ'ЦИЯЛЕ *с. к.* конституцион. *Конституцияле монархия.*

КОНСТРУКТИВ *с.* **1.** *тех.* Конструкциягә бәйләнешле. *Корылманың конструктив кимчелекләре.*

2. *кит.* Нәрсәгә дә булса нигез була алырлык, төпле. *Конструктив тәкъдим.*

КОНСТРУКТИВИЗМ *и.* XX йөз буржуаз сәнгатьтә иң чик формализмны һәм техницизмны алга сөрә һәм сәнгатьнең идеологик эшләгән танымый торган агым. [*Сәнгатьтә*] *немецлар конструктивизмның мөгаллимнәре булсалар да, зодчествода, архитектурада бу нәрсә күренми әле.* Г. Гали.

КОНСТРУКТИВИСТ *и.* Конструктивизм тарафдары.

КОНСТРУ'КТОР *и.* Конструкцияләүче, нәрсәнең дә булса конструкциясен төзүче кеше. [*Мортазинның*] *чыраеннан баш конструкторның чыгышын ошатмавын ачык күреп була иде.* Г. Әпсәләмов.

КОНСТРУ'КТОРЛЫК *и.* Конструктор һөнәре, профессиясе. — [*Сәфәр*] *укырга кайда кермәкче соң? - - - Спутниклар конструкторлыгына булгач, Мәскәүгәдер инде.* М. Рафиков.

КОНСТРУ'КЦИЯ *и.* **1.** Берәр корылма, машина төзелеше, аның аерым кисәкләренең урнашуы. — *Мондый конструкция хәзер һичкайда юк дип әйтерлек. Бу мичләрне күптән җимереп ташларга вакыт.* Ш. Камал. — *Менә шушы язу белән цех начальнигына барырсыз, ул сезгә төрле конструкциядәге самолетлар күрсәтер.* Т. Гыйззәт.

2. Катлаулы төзелешле корылма. *Җыелма конструкция. Металл конструкцияләрне конвейер ысулы белән блоклап җыю.*

3. *лингв.* Грамматик бәйләнеш ягыннан җөмләдә сүзләрнең (шулай ук кушма җөмлә составындагы җөмләләрнең) үзара урнашу, тезелү тәртибе. *Катлаулы синтаксик конструкцияләр.*

КОНСТРУ'КЦИЯЛӘУ *ф.* Нәрсәнең дә булса конструкциясен төзү. *Иштуган диплом эше итеп авто-*

мат-станок конструкцияләргә уйлый иде. Г. Әпсәләмов.

КО'НСУЛ *и.* 1. Икенче бер дәүләттә яшәп, үз дәүләтенең һәм аның гражданнарының интересларын гәүдәләндерә, яклый торган хөкүмәт вәкиле. [*Бу гостиницада*] *хәзер англичан миссиясе, әфган консуллары торалар.* Ш. Усманов.

2. *тар.* Борынгы Рим республикасында сайлаулы югары хезмәт урынындагы кеше титулы; шул титулны алган кеше. — *Тиздән ул* [*Красс*] *сенатка менәр. Консул булыр.* Н. Исәнбәт.

3. *тар.* Франциядә консуллык чорында (1799—1804 еллар) югары башкару власте үз кулларында булган өч кеше титулы; шул титулны алган кеше.

КО'НСУЛЛЫК *и.* 1. Консул булу вазифасы, хезмәте. *Консуллыктан төшеру.*

2. Башка бер дәүләттә консул (1 мәгъ.) җитәкчелегендәге дәүләт вәкиллеге; шул вәкиллек урнашкан бина. [*Муса:*] *Әгәр син исән калсаң, - - - аны* [*шигырьләр дәфтәрен*] *безнең Совет консуллыгына кертеп тапшыр.* Н. Исәнбәт.

3. Борынгы Римда республика белән консул идарә иткән чор.

4. Франциядә: Наполеон Бонапарт властька килгәннән алып (1799 елның 9 ноябре) империя игълан ителгәнгә кадәр (1804 ел) булган чор.

КО'НСУЛЬСТВО *и. к.* консуллык 2. *Франциядә СССР үзәге шул йортта урнаша. Икенче бер кварталда зур, яхшы, чиста йортта безнең генеральный консульство җирләшә.* Г. Гали.

КОНСУЛЬТАНТ *и.* Консультация (1 мәгъ.) бирүче кеше. *Кашшафның консультанты Таня булды. Ул Кашшафның сорауларына бик тулы җавап бирә.* Р. Төхфәтуллин.

КОНСУЛЬТАНТЛЫК *с.* Консультациягә бәйләнешле, консультация характерындагы. [*Җәгъфәрнең*] *тагын берничә урында консультантлык эшләре дә бар иде.* Г. Әпсәләмов.

КОНСУЛЬТАТИВ *с.* Киңәш итү, фикер алышу характерындагы. *Политик консультатив комитет утырышы. Коммунистлар һәм эшчеләр партияләренең консультатив очрашуы.*

КОНСУЛЬТА'ЦИЯ *и.* 1. Белгечнең нинди дә булса мәсьәлә буенча киңәше, күрсәтмәсе. *Әдәби консультация бүлеге.* □ *Армия штабына консультация алырга барам.* Т. Гыйззәт. || Укытучының укучыларга предметны үзләштерүдә өстәмә ярдәме; шундый ярдәм күрсәтелә торган махсус занятие. [*Заһид:*] *Сез әле имтихан алырга кайтып җитәрсез, консультацияне үзем уздырырмын.* А. Расих.

2. Белгечләрнең нинди дә булса мәсьәлә буенча киңәшмәсе. *Очрашуда катнашучылар үзара кызыксындыру тудыра торган мәсьәләләр буенча консультация үткәрделәр.* Соц. Тат.

3. Аерым мәсьәләләр буенча белгечләр катнашында киңәшләр, күрсәтмәләр бирә торган учреждение. *Юридик консультация. Балалар поликлиникасы һәм консультациясе.* □ *Йортларның күбесе иске, әүвәлге нык һәм әре кирпечләрдән салынган. - - - Хатын-кызлар консультациясе шундый йортларның берсендә урнашкан икән.* Э. Касыймов.

КОНСЫЗ *с.* Оятсыз, әдәпсез, сансыз; дорфа мөгамәләле, кырыс. [*Җәләш*] *үзе баладан ук бик кызу да, усал да, консыз да иде.* Г. Ибраһимов. *Гаҗәп сезнең халык!.. бигрәк канәгатьсез вә бик консыз.* М. Гафури.

КОНТАКТ *и.* 1. *тех.* Ике үткәргечнең берсеннән икенчесенә электр тогы үтәрлек итеп ялгануы, тоташуы; электр чылбырында чыбыкларның тоташкан урыны яки махсус тоташтыру җайланмасы. [*Галим*] *звоноклар үткәрде, янган контактларны алмаштырды.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Шундый тоташуны тәэмин итә торган. *Контакт ачкычы. Контакт чыбыклары.*

2. *күч.* Тыгыз бәйләнеш, үзара килешеп, ярдәмләшеп эшләү. *Экономик контакт.* □ *Тыңлаучылар белән лектор арасында җепләр ныгыганнан-ныгый, контакт көчәйгәннән-көчәя.* А. Расих. — *Безгә, Якуп туган, революцион контактта эшләргә кирәк.* И. Гази. || Очрашу, бергә булу, якыннан аралашу хәле. *Авыру белән контактта булу.*

КОНТА'КТЛЫ *с.* Контакты (1 мәгъ.) булган. *Контактлы каршылык. Контактлы үткәргеч.*

КОНТАМИНА'ЦИЯ *и.* 1. Сөйләгәндә, язганда ике яки берничә вакыйганы бергә бутау.

2. *лингв.* Бер-берсенә якын, охшаш ике форма, сүз яки тәгъбирнең берләшүеннән яңа форма, мәгънә яки тәгъбир барлыкка килү күренеше. (Мәсәлән: „Кичер, кода, гаеп бездә шул, дим, Сыйпаштырам салпы ягыннан" дигән Ш. Маннур мисалында *йон уңаена сыйпау* һәм *салпы якка салам кыстыру* фразеологик әйтелмәләре контаминацияләнгән.)

КОНТАМИНА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Контаминация ясау. *Сөйләмдә әйтемнәрне контаминацияләп куллану күренеше.*

КОНТЕ'ЙНЕР *и.* 1. *махс.* Йөк автомобильләрендә, тимер юл платформаларында, су юлы транспортында товарны төрмичә төяп йөртү өчен кулланыла торган махсус җайланмалы зур әрҗә. *Контейнерлар белән киләсе нәрсәләр килеп җитте.* Б. Камалов. *Киләсе кварталда, су юллары өзелгәнче, контейнерлар кайтырга тиеш.* Э. Касыймов.

2. Космик корабльдә фәнни аппаратура урнаштыра торган бүлек.

КОНТЕ'ЙНЕРЛАУ *ф.* Контейнерга урнаштыру.

КОНТЕ'ЙНЕРЛЫ *с.* Контейнерлап төялгән. *Контейнерлы йөкләр.*

КОНТЕКСТ *и.* Текстның мәгънә ягыннан бер бөтен булган һәм үзенә кергән сүзнең яки тулы бер фразаның мәгънәсен ачып бирә торган өлеше.

КОНТЕКСТУАЛЬ *с.* Контекстка мөнәсәбәтле. *Контекстуаль кулланыш. Сүзнең контекстуаль мәгънәсе.*

КОНТИНГЕНТ *и.* 1. *кит.* Берәр коллектив, учреждение, оешма, армия һ. б. ш.ның составы, аның карамагында булган барлык кешеләр. *Укучылар контингенты.* □ *Юллар төзү идарәсендә контингент чыннан да чуар.* М. Хәсәнов.

2. *махс.* Билгеле бер максатлар өчен нәрсәгә дә булса куелган чик, норма. *Читкә чыгару товарлары контингенты.*

КОНТИНЕНТ *и. геогр.* Океаннар, диңгезләр белән чолганып алынган бик зур мәйданлы коры җир; материк. *Октябрь революциясенең маягы барлык континентлар халыкларының юлын балкыта.* Каз. утл. *Монда яшәүчеләрнең тормышы да ике континентның* [*Европа һәм Азиянең*] *капма-каршы табигатен чагылдыра.* Э. Фәйзи.

КОНТИНЕНТАЛЬ *с.* Континентта булган, континентка хас, континентта урнашкан. *Континенталь илләр. Континенталь халык.*

Континенталь климат — диңгездән бик ерак урнашкан һәм корылык, эссе җәй, салкын кыш характерлы булган өлкәләргә хас климат.

КОНТИНЕ'НТАРА *с.* Континентлар арасында башкарыла, файдаланыла торган. *Континентара баллистик ракета.*

КОНТОР *и. сөйл. к.* контора. *Башта конторга керергә, управляющий белән сөйләшергә кирәк иде.* И. Гази.

КОНТО'РА *и.* Учреждениеләрдә һәм предприятиеләрдә административ-канцелярия бүлекләренең яки (күпчелек хуҗалык һәм финанс эшләренә бәйләнешле) мөстәкыйль учреждениеләрнең гомуми атамасы. *Минем ирем Шакир исемле кеше, Садыйк байларда конторада хезмәт итә.* Ш. Камал. || Шундый бүлек яки учреждение урнашкан бина, бүлмә. *Заготзерно конторасының тәрәзәсеннән карап торучы хезмәткәр тау битендә кырык сигез олау санады.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Конторага бәйләнешле. *Контора эше теләсә кемгә тәтеми, андый җылы урыннар бик санаулы.* Г. Бәширов. [*Җыенда*] *зур эш булырга тиешлеге әллә кайдан сизелеп тора, чөнки контора кешеләре дә килгәннәр иде.* Ф. Хөсни.

Контора өстәле — язу өстәле. *Сул тарафта бер контора өстәле, тәрәзә араларында көзгеләр, стена буйларында урындыклар.* Г. Камал.

КОНТО'РКА *и.* 1. *сөйл.* Контора урнашкан кечерәк кенә бүлмә. *Надежда Николаевна конторкага кергәндә, Назиров - - - нидер язып утыра иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Аягүрә торып яки биек урындыкка утырып эшләү өчен сөзәк такталы биек өстәл. *Кибет хуҗасы - - - почмактагы конторкада нәрсәдер саный, безгә дустанә елмая.* Р. Мостафин.

КОНТОРЧЫ *и.* Контора хезмәтчесе.

КОНТО'РЩИК *и. сөйл. к.* конторчы. *Байлар түгел, аларның - - - конторщиклары да безнең кәбек кешеләр белән рәтләп сөйләшмиләр.* М. Гафури.

КОНТО'РЩИКЛЫК *и.* Конторщик булу, конторщиклык хезмәте. [*Зәкәрия:*] *Берәр җирдә конторщиклык урыны эзләргә туры килә.* Ф. Әмирхан.

КОНТР- Кушма сүзнең беренче кисәге, икенче кисәгеннән аңлашылган мәгънәгә каршы куюны, актив каршылык күрсәтүне белдерә, мәсәлән: **контралым, контрудар, контрпроект, контрчара, контрманевр.**

КОНТР *и. сөйл.* Контрреволюционер. — [*Пролетариат*] *үзенең бер көрәшчесе урынына ун мең, йөз мең контрның корбанын сораячак.* Ф. Сәйфи-Казанлы. | *с. мәгъ.* — *Правлениегә җыен контр меньшевикларны утыртып куйгансыз да шуларның сүзләре белән йөрисез.* Ш. Камал.

КОНРАБА'НДА *и.* 1. Пошлина салынган яки тыелган товарларны, кыйммәтле әйберләрне яшерен рәвештә дәүләт чиге аша бер илдән икенче илгә чыгару. *Контрабанда белән шөгыльләнү.*

2. Шундый юл белән кулга төшерелгән яки шундый максат өчен билгеләнгән товар, кыйммәтле әйберләр. *Николай күбрәк контрабанда белән эш йөртә. Байларның малларын, яхшы гына хак белән алып, чик аша үткәрә.* Ә. Айдар.

3. *күч.* Нинди дә булса тыелган фикерләрне, карашларны, эшләрне яшерен рәвештә үткәрү; шулай үткәрелгән фикерләр һ. б.

КОНТРАБАНДИСТ *и.* Контрабанда белән шөгыльләнүче. [*Әхмәт*] *ышанычлы контрабандистлар өйрәткән юл белән, Кавказ таулары аша, Төркиягә качып чыккан.* Ш. Маннур. *Юк, кача алмас, ычкына алмас Контрабандистларның көймәсе.* Н. Исәнбәт.

КОНТРАБАС *и.* Зур скрипкага охшаган иң түбән яңгырашлы музыка коралы. *Соңгы вакытларда җиңел музыканы гитара, аккордеон, контрабас, кларнет кебек йомшак тавышлы* [*уен кораллары*] *белән башкару ишетелә башлады.* Ж. Фәйзи.

КОНТРАГЕНТ *и. махс.* Договор нигезендә үз өстенә нинди дә булса йөкләмәләр алган кеше яки учреждение.

КОНТР-АДМИРАЛ *и.* Хәрби флотта адмиралдан ике чинга түбәнрәк дәрәҗә.

КОНТРАКТ *и.* Якларның үзара нинди дә булса **йөкләмәләр** үтәргә алынуына бәйләнешле язма килешү. [*Малик*] *тирә-як авыллардан казнага тире-яры, сүс, йомырка җыю өчен контракт төзергә йөри.* И. Гази. [*Энгельгард*], *үзе Петербургка күчкәч, Тарасны да шунда алдырып, Шираев дигән бер адәмгә, контракт белән, рәсем һөнәрханәсенә бирә.* Г. Ибраһимов.

КОНТРАКТАНТ *и. махс.* Контракт буенча өстенә берәр йөкләмә алган оешма яки кеше.

КОНТРАКТАЦИОН *с.* Контрактациягә бәйләнешле. *Контрактацион йөкләмәләр. Контрактацион договор.*

КОНТРАКТА'ЦИЯ *и.* 1. Билгеле бер срок һәм билгеле бер шартлар белән нәрсә дә булса алу яки аны файдалану турында контракт төзү эше.

2. Хәзерләүче оешмалар белән колхозлар, совхозлар һәм аерым хуҗалыклар арасында һәр елны төзелә торган договор нигезендә авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү системасы.

КОНТРАКТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Контрактация (2 мәгъ.) үткәрү. *Игеннәрне контрактацияләү. Авыл хуҗалыгы продуктлары һәм чимал контрактацияләү договоры.*

КОНТРА'ЛЬТО *и. муз. иск.* Хатын-кызларда иң калын тавыш. || Шундый тавышлы хатын-кыз.

КОНТРАМА'РКА *и.* Театрга, циркка һ. б. ш. урыннарга түләүсез керү өчен билет урынына бирелә торган талон. [*Театрга килүчеләрнең берсе:*] *Минеке бит билет түгел, контрамарка!* Г. Камал.

КОНТРАПУНКТ *и. муз.* Берничә мөстәкыйль, ләкин бер үк вакытта яңгырый торган көйләрне, тавышларны бер гармоник бөтенгә берләштерү сәнгате. *Хәбир, мелодик сәләте булуга карамастан, форма белән логиканы тоймый, гармониядән аксый, контрапунктны аңламый.* Ш. Хөсәенов.

КОНТРАСТ *и.* 1. Берәр яктан кискен аерылып торган капма-каршылык. *Көнчыгыш гомер-гомергә үзенең әкияттәгечә байлык һәм кабердәгечә ярлылык контрастлары белән данлы ил.* Сов. әд. *Шагыйрь әйтергә теләгән төп иҗтимагый-политик идеясен - - - кискен контраст куюлар белән ачып сала.* Х. Госман. || *с. мәгъ. к.* контрастлы 1. *Контраст чагыштырулар.*

2. Сынлы сәнгатьтә, фотода: ачыклыкта, буяуларның төсендә кискен аерма. *Төс контрастлары.* || *с. мәгъ. к.* контрастлы 2. *Контраст буяулар. Контраст бизәкләр.*

КОНТРАСТЛЫ *с.* 1. Кискен үзгәрешле, капма-каршылыклы. *Контрастлы күренешләр.* □ *Октябрь дхырында температура кискен контрастлы булды.* Соц. Тат.

2. Сынлы сәнгатьтә, фотода: ачыклыкта, буяуларның төсендә кискен аерма булган. *Контрастлы сурәт.* || Шундый аерма булдыра торган. *Контрастлы кәгазь.*

КОНТРАСТЛЫК *и.* Контраст булу сыйфаты. *Дала белән янәшә бирелгән йөз яшәр Миңлебай картның уйлары әүвәлге белән бүгенгенең контрастлыгын тоярга ярдәм итә.* Г. Ахунов.

КОНТРАСТЛЫЛЫК *и.* Контрастлы булу сыйфаты. [*„Матур туганда“ романында*] *контрастлылык, капма-каршы кую аерым персонажларның бирелешендә дә саклана.* А. Сайганов. *Исмәгыйль Һилалов башкарган* [*музыкаль*] *әсәрләр үзләренең форма төзелеше, контрастлылыгы белән камил иделәр.* Ж. Фәйзи.

КОНТРАТА'КА *и.* Һөҗүм итүче дошманга каршы оборонада торучы якның җавап атакасы; атакага каршы атака. *Контратакага күчү.* □ *Төнге контратака белән дошман безнең частьларга бик нык якынайган.* Каз. утл.

КОНТРАТА'КАЛАУ *ф.* Контратака ясау, контратакага бару. *Безгә ашыгырга кирәк, — диде Урманов. — Финнар контратакалыйлар.* Г. Әпсәләмов.

КОНТРИБУ'ЦИЯ *и.* Җиңүче дәүләт тарафыннан җиңелгән дәүләттән түләтелә торган салым. || Сугыш белән басып алынган территорияләрдә халыктан акчалата яки әйберләтә җыела торган салым. [*Аклар*] *авылга контрибуция салганнар: мең пот иген, егерме биш ат, утыз баш сыер, йөз баш сарык.* И. Гази. — *Шәһәргә салынган контрибуция түләнеп беткәнче, сезне заложник итеп алабыз.* М. Галәү.

КО'НТРЛАНУ *ф. сөйл.* Контр булу, контрга әйләнү. [*Гали*] *Колчак ягында, ирекле агитатор булып, контрланып йөри.* Г. Ибраһимов.

КО'НТРЛЫК *и.* Контр булу. *Алар - - - берсен берсе контрлыкта гаепләштеләр.* Һ. Такташ.

КОНТРМИ'НА *и. хәрби.* Оборона корылмаларына якын юлларны дошман минёрларыннан саклау өчен куелган мина.

КОНТРОЛЁР *и.* Кемне яки нәрсәне дә булса тикшерү, контроль ясау, күзәтү бүрычы йөкләнгән хезмәткәр. *Җәмәгать контролёры.* □ *Детальне Валуйко үзе ОТКга алып барып тамга суктыра, бик ашыгыч булганда суктырып тормый, фәләнне алдым, билге куегыз, дип, контролёрларга кычкыра гына.* Г. Әпсәләмов. *Перрон ишеге төбенә бөтерелгән мыеклы, эре кыяфәтле контролёр басты.* К. Нәҗми.

КОНТРОЛЁРЛЫК *и.* Контролёр хезмәте.

КОНТРО'ЛЛЕР *и. махс.* Электродвигательләр эше белән идарә итә торган прибор (трамвайларда, троллейбусларда, электровозларда һ. б.).

КОНТРОЛЬ *и.* **1.** Тикшерү максаты белән күзәтү; тикшерү. *Даими контроль астында тоту.* □ *Бабай безнең бөтен дәресләрне контрольгә алды.* Э. Касыймов. || *с. мәгъ.* Тикшерә торган, контрольлек итү хокукы бирелгән. *Контроль органнар. Контроль постлар кую.* □ [*Сәрвәрев:*] *Контроль бүлеге нәрсә карагач? Ни өчен бракка юл куйган?* Р. Ишморат. || *с. мәгъ.* Контроль ясау, тикшерү өчен билгеләнгән. *Контроль диктант. Контроль аппаратура. Контроль үлчәү.*

2. Нәрсәнең дә булса эшчәнлеген контрольләүче учреждение. *Дәүләт контроле.*

3. *к.* контролёр. *Зур залның ишеге төбендә тагын бер контроль куелган иде.* Г. Ибраһимов.

Контроль-үлчәү приборы *тех.* — тикшерү, үлчәү операцияләрен автоматик рәвештә башкара торган прибор.

КОНТРОЛЬЛЕК *и.* Контроль ясау, тикшерү-күзәтү эше. [*Приискага*] *байлар килгәннән соң,* [*эшчеләр өстеннән*] *контрольлек тагын да көчәйде.* М. Гафури.

Контрольлек итү — контроль ясау.

КОНТРПАР *и. тех.* Пешкәкнең хәрәкәтен тиз генә туктату һәм шуның белән машинаны тормозлау өчен пар машинасының цилиндрына җибәрелә торган пар. *Паровоз, контрпар чыгарып, тормоз бирде.* Ш. Усманов.

КОНТРРАЗВЕ'ДКА *и.* Дошман разведкасына, шпионнарына, диверсантларына каршы хәрәкәт итә, көрәшә торган махсус оешма. — [*Бу кешегә*], *бер блиндажга алып кереп, ныклы тентү ясагыз. Мин монда конвой әзерли торам. Контрразведкага озатырбыз,* — *диде Цветков.* Ф. Кәрим.

КОНТРРАЗВЕ'ДКАЧЫ *и.* Контрразведкада эшләүче кеше.

КОНТРРАЗВЕ'ДЧИК *и. к.* контрразведкачы.

КОНТРРЕВОЛЮЦИОН *с.* Революциягә каршы юнәлтелгән, аңа дошман булган. *Контрреволюцион корткычлык.* □ *Тимер юлчылар Корниловның контрреволюцион гаскәрләре төялгән поездларны үткәрмиләр.* И. Гази.

КОНТРРЕВОЛЮЦИОНЕР *и.* Контрреволюция яклы, контрреволюциягә катнашучы кеше, революция дошманы. — *Безгә дә, безнең эшче-крестьян халкына да контрреволюционерларның башлары өстеннән азатлыкка барырга туры килә.* Г. Ибраһимов.

КОНТРРЕВОЛЮЦИОНЕРЛЫК *и.* Контрреволюционер булу. — *Без* [*Хәсән Кадыйровны*] *контрреволюционерлыкта - - - гаепләдек.* Һ. Такташ.

КОНТРРЕВОЛЮ'ЦИЯ *и.* Бетүгә йөз тоткан яки бәреп төшерелгән эксплуататор сыйныфларның революциягә кадәр булган тәртипләрне һәм үз өстенлекләрен кайтару өчен революциягә каршы реакцион көрәше. *Контрреволюция җиңү бәйрәмен итәргә торганда гына, көнчыгыш ягыннан кайтып килгән биш йөз кешелек кызыл гвардия отряды, аларны таратып, шәһәрне коткарды.* Ш. Усманов. — *Без, фронтларда кораллы контрреволюцияне бетереп, ил батырлары исемен алдык.* Х. Садрый.

КОНТРРЕВОЛЮ'ЦИЯЧЕ *и. к.* контрреволюционер. *Карагруһлар, аларның союзниклары эсерлар, меньшевиклар әле монда бик көчле, чөнки монда алар контрреволюцияче казачийларга таяна.* Ш. Камал.

КОНТРУДАР *и. к.* контрһөҗүм. [*Дошман*] *Мариенбург юнәлешендә көчле контрудар хәзерләде.* Каз. утл.

КОНТРХӘРӘКӘТ *и.* Хәрәкәткә каршы хәрәкәт. [*Герасимов*] *бөтен контрхәрәкәтнең, контратакаларның һәммәсенең дә иң кечкенә тармакларынача үзе турыдан-туры җитәкчелек итәргә тотынды.* Г. Ибраһимов.

КОНТРЧАРА *и.* Каршы, җавап буларак эшләнгән чара. *Лагерь комитеты да контрчаралар күрә башлады.* Н. Дәүли.

КОНТРһӨҖҮМ *и.* Оборона сугышлары барышында хәзерләнеп, дошман һөҗүм итүдән туктаганнан соң үткәрелә торган һөҗүм. *Безнекеләр дошманның алга китүен бөтен фронт буйлап туктатканнар, ә кайбер участокларда контрһөҗүмгә күчкәннәр.* Г. Әпсәләмов.

КОНТУ'ЖЕН: контужен булу *сөйл.* — контузияләнү. — [*Мин*] *бик нык контужен булган идем.* Ш. Камал.

КОНТУ'ЗИЯ *и.* Организмның тыштан яраланмый гына, тулысынча яки өлешчә зарарлануы, имгәнүе, зәгыйфьләнүе (якында гына снаряд яки бомба шартлау һ. б. нәтиҗәсендә). [*Самойлов:*] *Контузиядән колагым начар ишетә, бераз телем тотлыга.* Т. Гыйззәт. *Ул сугышта, дошман бомбасы астында калып, контузия алган.* Н. Дәүли.

КОНТУ'ЗИЯЛЕ *с.* Контузияләнгән, контузияләнеп калган. *Военком, контузияле башын чайкалтып, тотлыга-тотлыга:* — *Миң — бәхет билгесе ул,* — [*диде*]. Каз. утл.

КОНТУ'ЗИЯЛӘНУ *ф.* Контузия алу. *Яшен сугудан контузияләнү.*

КО'НТУР *и.* Предметның тышкы сызымы, рәсеме. [*Хәзер трассада*] *булачак автостраданың контурларын күрергә була.* М. Мәхмүтов. || Предметның сызыклар белән генә ясалган сурәте.

КО'НТУРЛЫ *с.* Контурдан гыйбарәт булган. *Контурлы рәсем. Контурлы сырлар.*

Контурлы карта — исемнәрен атамыйча, контур сызыклар белән генә коры җир һәм сулар төшерелгән географик карта. **Контурлы линия** — ноктадардан торган өзек-өзек сызык.

КО'НУС *и. мат.* Турыпочмаклы өчпочмакны катетларының берсе тирәсендә әйләндерүдән килеп чыга торган геометрик җисем. *Орыну конусы. Киселгән конус. Дүләнә конусы.* || Формасы белән шундый җисемгә охшаш предметлар турында. *Берничә минуттан безнең янга - - - ябык иңбашларына хәтле төшеп торган конус сыман зур эшләпәле, яланаяклы, бераз бөкрерәк булган кытай карты килеп туктады.*

А. Шамов. || *с. мәгъ.* Конус формасындагы, конуслы. *Ялкын, тирә-якны балкытып, йөрәккә шом салып, дулый-дулый котырына, заводның челтәр-челтәр корпуслары, конус түбәләре - - - барысы берьюлы яна төсле төела иде.* Г. Ахунов.

КО'НУСЛЫ *с.* Конус формасындагы. *Конуслы кисемнәр. Конуслы вулкан түбәләре.*

КОНФЕДЕРА'ЦИЯ *и.* Нинди дә булса җәмәгать оешмаларының, шулай ук мөстәкыйль дәүләтләрнең берләшмәсе, союзы. *Африка илләре хезмәт ияләренең гомуми конфедерациясе.*

КОНФЕРАНС *и. театр.* Конферансьеның программа номерларын белдерүе, шул номерларга аңлатма бирүе һ. б. ш.; шушы чыгышларның тексты. *Уңышлы конферанс.*

КОНФЕРАНСЬЕ *и. театр.* Эстрада чыгышында концерт программасы номерларын белдереп торучы, кайвакыт, номерлар арасындагы паузада, үз чыгышлары белән дә тамашачыларны җәлеп итүче артист. *Конферансье кылана-кылана программаны белдерде.* Г. Әпсәләмов.

КОНФЕРЕНЦ-ЗАЛ *и.* Тантаналы утырышлар, конференцияләр залы.

КОНФЕРЕ'НЦИЯ *и.* Аерым мәсьәләләрне тикшерү өчен дәүләтләр, партия, иҗтимагый, фәнни һ. б. оешмалар тарафыннан җибәрелгән делегатларның, вәкилләрнең җыелышы, киңәшмәсе. *Район партия конференциясе. Тынычлык яклаучыларның халыкара конференциясе.* □ [*Гайфуллинны*] *конференциянең мандатлар комиссиясенә рәис итеп сайладылар.* Г. Ибраһимов.

КОНФЕТ *и.* Шикәргә төрле тәмләткеч азыклар кушып кайнатып, кечкенә шарчык, озынчык, мендәрчек һ. б. формаларда эшләнгән татлы кондитер әйбере. *Шоколадлы конфет. Кәгазьле конфет.* □ *Өстәл өсте конфетлар, алма, сумсалар белән тулды.* Г. Минский.

КОНФЕТЛАНУ *ф. сөйл.* **1.** Кыланчыклану, кылану. *—Конфетланучы халыкны җенем сөйми.* Г. Әпсәләмов.

2. Кемнең дә булса көен көйләү, артык игътибар бирү. *Полковникның кровате янына барып, аны төрткәли башладым. Ул исерек. - - - Ләкин аның белән озак конфетланырга вакыт юк.* Ә. Айдар.

КОНФЕТЛАП *рәв.* Конфет белән, конфет кабып. *— Чәй эчерәбез үзеңә Баллап, майлап, конфетлап.* М. Гафури.

КОНФЕТЛЫ *с. күч.* Төче, җитди булмаган, ялагай. *Конфетлы сүзләр.*

◇ **Конфетлы уйнау** — шаяру, җитди сөйләшмәү. [*Вахитов:*] *Сез бик бормакай кеше. Без бит сезнең белән конфетлы уйнамыйбыз.* Н. Исәнбәт.

КОНФЕТТИ *и.* Бал-маскарадларда күңел ачучыларның бер-берсенең өстенә сибәр өчен ваклап, түгәрәкләп киселгән төрле төстәге кәгазь кисәкләре. *Өч хатын почмакта конфетти сата.* Г. Тукай. *Бөтен кичә буенча залда конфетти сугышы, серпантин чолгашы һәм почта уены булып торачак.* Ф. Әмирхан.

КОНФИГУРА'ЦИЯ *и. кит.* Нәрсәнең дә булса тышкы күренеше, сызымы, сурәте, формасы. *Тау кыялары конфигурациясе.* □ *Ул кайбер детальләрнең конфигурацияләрен үзгәртү турында берничә тәкъдим керткән.* Г. Әпсәләмов. || Нинди дә булса предметларның үзара билгеле бер тәртиптә торышы, куелышы, урнашуы. *Йолдызлар конфигурациясе.*

КОНФИДЕНЦИАЛЬ *с. кит.* Яшерен, башкалар белмәскә тиешле. [*Заһид:*] *Мәдинәкәй, минем сиңа конфиденциаль сүзем бар.* А. Расих.

КОНФИСКА'ЦИЯ *и.* Кемнең дә булса акчасын, мал-мөлкәтен дәүләт файдасына бөтенләйгә көчләп алу эше. *Малик бөтен байлыгына конфискация ясарлар дип һич ышанмый иде.* И. Гази.

КОНФИСКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Конфискация ясау, конфискация үткәрү. *Алпавыт җирләрен конфискацияләү.*

КОНФЛИКТ *и.* Капма-каршы як, фикер, көчләрнең бәрелеше; низаг, кискен бәхәс. *Конфликтка керү.* □ *— [Сез, Шәйхерамов,] кафедрада барлык кеше белән конфликтта икәнсез!* А. Расих. *Сәхнәдә - - - хәрәкәт аша конкрет күрсәтелгән конфликт бик тиз киеренке атмосфера тудыра.* М. Җәлил. || Кайвакыт кораллы бәрелешкә китерә торган халыкара мөнәсәбәтләрдәге кискенлек, киеренкелек. *Хәрби конфликт. Халыкара конфликтларның куркынычлы учаклары.* □ *— Безнең Бохара әмире белән булган конфликтыбыз әле булса басылганы юк.* Ш. Усманов.

Конфликт комиссиясе — предприятие, учреждение администрациясе белән хезмәткәрләр арасындагы конфликтны хәл итә торган комиссия. *Конфликт комиссиясе эшне озакка сузарга теләмәде.* Х. Госман.

КОНФЛИ'КТЛЫ *с.* Каршылыклы, бәхәсле. *Конфликтлы мәсьәлә. Конфликтлы эш.* □ *Аннан егет белән кызның, — ди, — Араларын бераз боздыр,—ди.— Конфликтлы булыр китабың, Эше бик күп түгел бит аның.* Б. Рәхмәт.

КОНФО'РКА *и.* **1.** Күмер салу һәм чәйнек кую өчен самовар торбасының өстенә кидерелә торган челтәрле җайланма. *Самовар конфоркасы.*

2. Плитада аш-су пешерү, кайнату савытлары утырту өчен махсус түгәрәк тишек. || Шул тишеккә куела торган тимер түгәрәкләр. || Газ плитасында, газны яндырып, аш-су пешерү, кайнату савытлары утырта торган җайланма. *Газ плитасы конфоркасы.*

КОНЦЕНТР *и. мат.* Уртак үзәге булган төрле зурлыктагы әйләнәләрнең берсе.

КОНЦЕНТРАТ *и.* **1.** Киптереп, калыплап төрелгән әзер азык. *Карабодай концентраты. Борчак концентраты.* □ *Хәдичә апа минем концентраттан ботка пешерде.* А. Шамов. *Чардин әле сугышка кадәр үк армия тәэминатына кертелгән концентрат уйлап тапкан булган.* Каз. утл.

2. *а.-х.* Туклыклы матдәләргә бай булган терлек азыгы (мәсәлән, ашлык, түп, көрпә). — [*Терлекләргә*] *яшел азык та юк, концентрат та чамалы гына.* Г. Ахунов. || *с. мәгъ.* Туклыклы, витаминлы матдәләргә бай булган. *Гөләндәм* [*сыерларга*] *күбрәк концентрат азыклар бирергә кирәклеген куәтләде.* С. Рафиков.

3. *махс.* Казылма байлыкны алдан баету (концентрацияләү) ысулы белән алына торган чимал. *Апатит концентраты.*

КОНЦЕНТРАЦИОН: концентрацион лагерь — капиталистик илләрдә политик тоткыннарны, хәрби әсирләрне ябып тоту урыны. *Бу урында мин газап чиккән концентрацион лагерь иде.* Н. Дәүли.

КОНЦЕНТРА'ЦИЯ *и.* **1.** Бер җиргә җыйналу, тупланыш. *Көчләр концентрациясен тигезләү. Капитал концентрациясе. Производство концентрациясе.*

2. *хим.* Билгеле бер күләм эремәдә эретелгән матдәнең микъдары, куелыгы. *Эремәләр концентрациясе.*

3. *махс.* Киләчәктә эшкәртү, файдалану өчен,казылма байлыкларның андагы техник һәм экономик яктан кыйммәтлерәк өлешен бүлеп чыгару юлы белән баету ысулы. *Чималда кыйммәтле матдәләрнең концентрациясен арттыру.*

КОНЦЕНТРА'ЦИЯЛӘНҮ, КОНЦЕНТРА'ЦИЯЛӘШҮ *ф.* Бер тирәгә туплану, җыйналу. *Производствоның һәм капиталның концентрацияләшү процессы көчәю.* □ *Зур әдәби талант иҗатында хәрәкәтнең көче концентрацияләнә, җитлеккән югарылыкка күтәрелә.* Х. Госман.

КОНЦЕНТРА'ЦИЯЛӘУ *ф.* 1. Бер тирәгә туплау, җыйнау. *Җитештерү көчләрен концентрацияләү.*

2. *хим.* Куерту, куеландыру (мәсәлән, эремәне, кушылманы).

3. *махс.* Баету (мәсәлән, руданы).

КОНЦЕ'НТРИК *с.* Уртак үзәге булган, үзәктәш. *Концентрик түгәрәкләр.*

КОНЦЕ'ПЦИЯ *и. кит.* 1. Теге яки бу күренешләргә булган карашлар системасы; нинди дә булса күренешне аңлау-аңлату ысулы. *Политик концепция. Фәнни концепция.* □ *Такташ татар язма поэзиясе нигезендә үз иҗат концепциясен тудырды.* Х. Госман.

2. Иҗат әсәрендә күтәрелгән төп фикер. *Мәкаләдә күтәрелгән концепциянең бик ачык булуы.*

КОНЦЕРН *и.* Капиталистик монополияләрнең бер формасы буларак, гомуми финанс контрольлегенә нигезләнгән күп санлы сәүдә-промышленность предприятиеләре берләшмәсе. *Көнбатыш Германиянең финанс һәм промышленность концерннары.* □ *Әле бик күп еллар элек Фарбер концерны бу тауларны тишеп аммиак чыгарган.* Н. Дәүли.

КОНЦЕРТ *и.* 1. Музыкаль әсәрләр, эстрада, балет һ. б. номерлар белән билгеле бер программа буенча халык алдында яки радио, телевизор аша ясалган чыгыш. *Радио аша бәйрәм концертын тыңлау. Татар җыр һәм бию ансамбле концерты.* □ — *Сез, Зөфәр абый, спектакльгә караганда концертны ярата төшәсез ахрысы.* Ш. Камал.

2. Нинди дә булса бер музыка коралында оркестрга кушылып башкару өчен язылган зур музыкаль әсәр. *Скрипка белән оркестр өчен язылган концерт.* □ *Н. Җиһанов консерваториядә укыган елларында --- берничә фуго, сонатина, концерт, квартет һәм, ниһаять, беренче симфониясен яза.* М. Җәлил.

КОНЦЕРТИ'НО *и. муз.* 1. Алты кырлы кечкенә гармонь формасындагы музыка коралы.

2. Концерт (2 мәгъ.) тибындагы, җиңелрәк һәм кечерәк күләмле музыкаль әсәр.

КОНЦЕРТМЕ'ЙСТЕР *и. махс.* 1. Симфоник яки опера оркестрының солисты — беренче скрипкачы.

2. Симфоник яки опера оркестрында кыллы уен кораллары төркемнәренең берсенә (скрипкаларга, виолончельләргә яки альтларга) җитәкчелек итүче музыкант. *Скрипкалар концертмейстеры.*

3. Башкаручыларга үз партияләрен өйрәнүгә ярдәм итүче һәм аларга концертларда кушылып уйнаучы пианист. *1941 елның ахырында Рөстәм Яхин Казанга кайта, Татарстан радиосында концертмейстер булып эшли башлый.* Каз. утл.

КОНЦЕССИОН *с.* 1. Концессиягә (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле. *Концессион договор.*

2. Концессия нигезендә яшәп килгән, оештырылган. *Концессион тимер юл. Концессион магазин.*

КОНЦЕССИОНЕР *и.* Концессия алган кеше. *Яңа экономик политика вакытында сәүдәгәрләр һәм концессионерлар үз предприятиеләренә яшьләрне кертмәскә тырышалар иде.* Соц. Тат.

КОНЦЕ'ССИЯ *и.* 1. Дәүләт тарафыннан аерым предпринимательгә, чит ил фирмасына промышленность предприятиеләрен, җир-суларны файдалануга бирү-алу турында төзелгән килешү. *Нефть эзләү концессиясе.* □ [*Америка капиталистлары кысыклау аркасында*], *Англия капиталистлары Мексикада үзләре алган концессиядән ваз кичәргә мәҗбүр булдылар.* Ф. Әмирхан.

2. Шул килешү нигезендә оештырылган предприятие. *Чит ил концессияләрен национализацияләү.*

КОНЦЛА'ГЕРЬ *и. к.* концентрацион лагерь. —[*Җырны*] *бер концлагерь да, бер богау да тота алмый.* Н. Исәнбәт.

КОНЪЕКТУ'РА *и.* 1. *иск.* Гөман, юрама, фараз; шулай булса кирәк дип уйланылган нәрсә.

2. Фараз итүгә нигезләнеп, бозылган яки укуы мөмкин булмаган текстны төзәтү яки әлекке хәленә кайтару.

КОНЪЮНКТИ'ВА *и. анат.* Күз кабакларының эчке өслеген һәм күз алмасының алгы өлешен каплап торган лайлалы яры.

КОНЪЮНКТИВИТ *и. мед.* Конъюнктиваның ялкынсынуы (авыру).

КОНЪЮНКТУ'РА *и.* 1. *кит.* Берәр өлкәдә барлыкка килгән һәм нинди дә булса эшнең барышына йогынты ясауга сәләтле хәл, шарт; ситуация. *Халыкара конъюнктура.* □ *Яшь автор* [*үз әсәрендә*] *- - - иҗат интеллигенциясе арасында конъюнктурага карап эш итүче, карьера артыннан куучы типларны фаш итү, чын иҗат атмосферасы өчен көрәш проблемаларын куярга тели.* М. Әмир.

2. *экон.* Товарлыклы хуҗалыкның торышын чагылдырган характерлы билгеләр (бәяләрнең, эш хакының, продукция чыгару күләменең һ. б. үзгәрүе) җыелмасы. *Кыйммәтле кәгазьләргә булган сорау һәм тәкъдимнәрнең дәрәҗәсенә базар конъюнктурасының тирбәлүләре генә түгел, бәлки политик вакыйгалар да тәэсир итә.* Политэкономия.

КОНЪЮНКТУ'РАЧЫ *и. кит.* Теге яки бу хәлдән оста файдаланып, конъюнктурага карап, карашын төрлечә үзгәртүче, принципсыз кеше.

КОНЬКИ *и.* Аяк киеменә беркетеп боз өстендә шуу өчен эшләнгән тар тимер табан; тимераяк. *Конькида шуу.* □ *Өй алдында чаналар, чаңгылар, конькилар өелеп ята иде.* А. Алиш.

КОНЬКИЧЫ *и.* Конькида шуучы; конькида шуу спорты белән шөгыльләнүче. *Конькичылар ярышы.* □ [*Альбомның*] *икенче битендә конькичылар — Жукова белән Гончаренко.* Г. Мөхәммәтшин.

КОНЬЯК *и.* Виноград аракысын куып, аны озак вакыт имән мичкәләрдә саклап хәзерләнгән көчле исерткеч эчемлек. [*Фазыл Гөлзадәгә:*] *Аракы түгел, аппагым, коньяк. Биш йолдызлысы.* Р. Ишморат.

КО'НЮХ *и. сөйл.* Ат карау хезмәтендәге кеше. *Хәлим бүген дә, атына кичке башакны биреп чыккач, конюх янына кереп утырды.* Г. Гобәй.

КООПЕРАТИВ *и.* 1. *к.* кооперация 2. *Менә хәзер авылда кооператив төзергә йөрибез.* М. Гали. [*Пауль*] *хәзер авыл хуҗалыгы кооперативында трактор чы булып эшли икән.* Р. Төхфәтуллин. || *с. мәгъ.* Кооперативка караган, кооперативлаштырылган. *Кооператив оешмалар. Кооператив хуҗалык. Кооператив милек.* □ *Кооператив кибете янында берничә кеше тәмәке тартып сөйләшеп торалар иде.* Ш. Камал.

2. *сөйл.* Кооперация (2 мәгъ.) кибете. *Бу сорау аның уена --- кооперативта чиратта торганда һәм башка бик күп нәчинҗәсез эшләр эшләгәндә дә басты.* А. Шамов. *Сәхип --- әүвәле Хәбибуллиннарга керде, аннан кооперативка китте.* Р. Ильяс.

Кооператив-колхоз милке — СССРда социалистик милекнең бер формасы: аерым колхозлар яки кооператив берләшмәләр милке.

КООПЕРАТИВЛАШТЫРУ *ф.* 1. Кооперация (1, 2 мәгъ.) нигезендә берләштерү. *Һөнәр производствосын кооперативлаштыру.* □ *Социалистик дәүләтнең авылга материаль, финанс һәм оештыру ярдәме күрсәтүен Ленин миллионнарча вак крестьян хуҗалыкларын кооперативлаштыру бурычын уңышлы үтәүдә бик әһәмиятле шарт дип санады.* Политэкономия.

2. Социалистик илләр арасында яңа типтагы экономик хезмәттәшлек формасы: җитештерүне халыкара хезмәт бүленеше нигезендә оештыру. *Социалистик*

илләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә производствоны специальләштерү һәм кооперативлаштыру иң әһәмиятле нәрсәгә әверелде. КПСС тарихы.

КООПЕРАТИВЧЫ *и. к.* кооператор. *Тукыз авылыннан Тоболга Нури Кутков дигән кооперативчы килгән икән.* Ш. Маннур.

КООПЕРА'ТОР *и.* Кооперация (2 мәгъ.) системасында эшләүче хезмәткәр. *Игенчелек кооператорлары съезды.* || Сәүдә кооперациясендә эшләүче. — *Мин сезне кооператор Мортаза иптәшкә төшерермен. Аларның өйләре иркенрәк.* К. Нәҗми.

КООПЕРА'ЦИЯ *и.* **1.** Бер үк хезмәт процессында яки хезмәтнең үзара бәйләнгән төрле процессларында күп кешеләрнең бергәләп эшләүләренә нигезләнгән хезмәт оештыруның аерым бер формасы. *Хезмәт кооперациясе.* □ *В. И. Ленин крестьяннарны социалистик төзелешкә тарту юлын кооперациядә күрде.* КПСС тарихы.

2. Промысел, сәүдә, авыл хуҗалыгы һ. б. ш. эшләрне бергәләп алып бару өчен материал яки акча [пай] керткән кешеләрнең ирекле берләшмәсе. *Һөнәрчеләр кооперациясе.* □ [*Кригер Хөрмәтуллага:*] *Миңа акча кирәкми. Син миңа волость кооперациясе исеменнән язу гына бир.* Т. Гыйззәт.

3. *сөйл.* Кооперация (2 мәгъ.) кибете. *Хәзер абыем да, әнем дә авылда яши: берсе укытучы, икенчесе кооперациядә эшли.* Г. Ибраһимов

КООПЕРА'ЦИЯЛӘШТЕРҮ *ф. к.* кооперативлаштыру. *Кооперацияләштерү --- вак хосусый товар җитештерүчеләрнең хуҗалыгын тулысынча ирекле рәвештә эре социалистик предприятиеләргә берләштерүне күздә тота.* Политэкономия.

КООПЕРА'ЦИЯЛӘШҮ *ф.* Кооперация нигезендә берләшү.

КООПТА'ЦИЯ *и. кит.* Сайланып куелган нинди дә булса коллегиаль органны, өстәмә сайлаулар үткәрмичә, яңа членнар белән тулыландыру эше.

КООПТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Кооптация үткәрү. *Күп тә узмады, РСДРПның кооптацияләү юлы белән торгызылган һәм тулыландырылган яңа комитеты эшли башлады.* А. Расих.

КООРДИНАТ(ЛАР) *и.* Нинди дә булса ноктаның, объектның яссылык өстендәге яки пространстводагы торышын, урынын билгели торган зурлыклар. *Сәяхәт башлыгы, берни дәшмәстән, ягулыкның күпме калганын һәм ракетаның координатларын күрсәтә торган автоматны эшкә кушты.* А. Тимергалин. — *Сез безгә заводыгызның төгәл координатын эшләп бирегез. Бүген кич үк безнең егетләр барып бомбага тотарлар.* Г. Гобәй.

КООРДИНАЦИОН *с.* Координациягә бәйләнешле. *Координацион элемтә.*

КООРДИНА'ЦИЯ *и.* Үзара максатлы килешкәнлек, ярашканлык (эш, хәрәкәт һ. б. да). *Җитәкчелектә координация булмау.*

КООРДИНА'ЦИЯЛЕ *с.* Координацияләнгән, координациягә нигезләнгән.

КООРДИНА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Үзара максатлы килештерү, яраштыру (нинди дә булса эш-хәрәкәтләрне, күренешләрне). *Хуҗалык планнарын координацияләү. Фәнни тикшеренү эшләрен координацияләү.* □ *Генин,* [*артиллерияне*] *координацияләү! Санаулы минутлар гына калды, аннан соң авыл безнеке булачак!* Каз. утл.

КОПАЛ *и. махс.* Лак ясау өчен тропик агачлардан алына торган бик каты сумала.

КОПЁР *и. махс.* **1.** Шахта авызы өстендә күтәргеч урнаштыру, ныгыту өчен төзелгән гидротехник корылма. *Озын сафа буйлы спортчы егетләргә охшаган шахта копёрлары менә-менә туп куарга йөгереп китәрләр сыман.* Ш. Рәкыйпов.

2. Субайны каты җиргә яки зур тирәнлеккә кагып кертү өчен кулланыла торган махсус механик җайланма. *Пар копёры.* □ *Порт төзелешендә шпонт кагучы копёр тавышы ишетелеп тора.* Г. Әпсәләмов.

КОПИ'ЛКА *и. сөйл.* Акча җыю, саклау өчен тар ярыклы кечкенә тартма яки башка төрле савыт. [*Кошчыклар*] *үзләре кечкенә, авызлары зур.* [*Бөжәкләрнең*] *чыкканы бере, копилкага салган көмеш акча кебек, төшә дә китә.* Г. Гобәй.

КОПИРО'ВКА *и. сөйл.* Язу яки сызымның копиясен төшерү өчен кулланыла торган махсус кәгазь. || *с. мәгъ.* Шундый максат өчен билгеләнгән, хезмәт итә торган. *Копировка кәгазе.*

КО'ПИЯ *и. к.* күчермә. *Диплом копиясе.* □ *Ул хатларның берничәсен бергә чагыштырып карасаң, һәммәсе, берсе икенчесенең копиясе кебек, бертөсле булып чыга иде.* М. Гафури. — *Безгә бюро карарының копиясе кирәк.* М. Хәсәнов.

КОП-КОРЫ *с. Артык. дәр. к.* коры. *Аяк асты коп-коры.* И. Гази.

КО'ПРА *и.* Кокос пальмасы чикләвегенең киптерелгән төше (шуннан кокос мае алына). *Сингапур причалында яңа чабылган кыяк үләнен хәтерләткән бер ис борыныңа килеп бәрелә. Бу ис копра һәм кокос мае складларыннан килә.* Р. Мостафин.

КОПШАНГЫ *и. бот.* **1.** Ат тизәге белән туена торган каты яшькелт канатлы зур коңгыз, тирес коңгызы; *русчасы:* навозник. *Копшангы: — Хуш, сау булыгыз, мин Һиндстанга киттем, — дип очкан икән дә, тик юлда ат тизәге күргәч, шунда кунып калган, имеш.* Мәкаль.

2. *күч. сөйл.* Тиргәү, кимсетү сүзе буларак кулланыла. [*Алмаз Эсмеральдага:*] *Җитәр! Туктыйсыңмы, юкмы син, копшангы.* Н. Исәнбәт.

КОПЫ: копы бүрек *иск.* — колакчынсыз бүрекнең бер төре.

КОР [кор] *и. иск.* **1.** Чак, вакыт.

2. *диал.* Мохит, даирә.

КОРАБ *и. сөйл. к.* корабль. *Диңгезне ерып, кораб һаман алга бара.* А. Алиш. *Баш очыннан һава кораблары Тасма сузып китә еракка.* Г. Афзал. || *күч.* Комбайн турында. *Син йөртәсең, дустым, кырда зур корабны, Йөзгән кебек иркен диңгездә.* Г. Хуҗиев.

КОРАБЛЬ *и.* **1.** Диңгез-океаннарда йөзү өчен төзелгән зур судно. — *Тиздән, Волга диңгезе кораблләренә утырып, Кара диңгезгә барачакбыз.* Р. Ишморат.

2. *күч.* Һавада очу аппараты (зур самолет, дирижабль, космоска очу ракеталары). *Флагман корабле.* □ *Андриян* [*космик*] *корабльне кул белән идарә итеп карады.* К. Латыйпов.

КОРАК *и. диал.* Киң яфраклы, куыш сабаклы үлән. *Корама җыеп ил иткән, корак җыеп көн иткән.* Мәкаль.

КОРАЛ *и.* **1.** Һөҗүм итү яки саклану өчен хезмәт итә торган һәртөрле табигый яки махсус эшләнгән җайланма, әйбер. *Ату кораллары. Салкын корал. Атом-төш коралы.* □ [*Дошманның*] *әллә никадәр кораллары, обозларын кулга төшердек.* А. Шамов. *Табигать үгезгә мөгез, бүрегә үткен теш, арысланга көчле тырнак биргән. Бу әйтелгән кораллар барчасы да дошманның һөҗүменнән саклану өчендер.* Г. Тукай. || *күч.* Кемнең дә булса гаскәре, хәрби көче турында. *Рус коралының данын саклау.* || *с. мәгъ.* Корал җитештерү белән шөгыльләнә торган, корал саклый торган. *Корал заводы.* □ [*Гәрәй*] *җир астында, - - - рус эшчеләре белән бергәләшеп, корал склады асрый.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр эш башкарганда файдаланыла торган җайланма, инструмент. *Авыл хуҗалыгы кораллары. Эш кораллары. Җитештерү кораллары.* □ *Корал эшләр — ир мактаныр. Мәкаль.* — [*Насосны*] *монда гына төзәтеп булмый, — диде слесарь һәм кораллларын җыйнаштырырга кереште.* Ш. Камал. || Музыкаль көйләр чыгару, башкару өчен махсус эшләнгән инструмент. *Батыр егет үзенең уен коралында уйнарга телләде.* А. Алиш. — *Син гармоньны музыка коралына санамасаң да, мин әйтер идем: талантлы кеше кулында гармонь да — музыка коралы.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Нәрсәгә дә булса ирешү чарасы, ысулы. *Тәнкыйть - - - язучыларның иҗат практикасын алга әйдәү коралы булырга тиеш.* Г. Гали. *Бөек Ленин бабабызның Китаплары кулымда, һәрвакытта үткен корал Алар көрәш юлында.* Җыр.

Корал йөртүче — урта гасырларда: рыцарьның коралын йөртүче яшь сугышчы.

◊ **Корал (көче) белән** — сугыш белән, хәрби көч белән. *Мәсьәлә корал белән чишелү юлына [күчте].* Ш. Усманов. — *Сез хәзерге тормышны корал көче белән җимерүче оешмаларда актив әгъза булучылык белән гаепләнәсез.* Г. Ибраһимов. **Корал итү** — кем яки нәрсәне дә булса берәр максат өчен файдалану. *Һиммәтең итсәң корал, Шөбһәсез галиб булырсың.* М. Гафури. **Корал күтәрү** — 1) кемгә дә булса корал белән һөҗүм итү, янау. *Күрдегез сез аны: хыянәтче безгә каршы корал күтәрә.* Н. Исәнбәт; 2) корал тотып көрәшкә чыгу, баш күтәрү. *Әгәр Советлар - - - кораллы да, властьлы да, көчле дә булсалар, бер генерал да революциягә каршы корал күтәрергә кыймас.* И. Гази. **Корал ташлау** — 1) сугыш хәрәкәтләрен, корал белән каршылык күрсәтүне туктату. [*Хөсәен:*] *Коралларыгызны ташлагыз, - - - һәммәгез дә чигенегез.* Ф. Бурнаш; 2) коралсызлану (баш тарту, кискен ризасызлык белдерү йөзеннән). [*Һөҗүмгә*] *көчләп җибәрә башласалар, һичбер атышсыз-нисез, бөтен часть белән корал ташларга кирәк.* М. Гали. **Коралга тотыну (ябышу)** — кораллану, кораллы көрәшкә күтәрелү. *Пролетариат, коралга ябышып, тизлек белән гаскәри көч хәзерли башлады.* Ш. Усманов.

КОРАЛАЙ *и. иск.* Кыр кәҗәсе. *Атның киеге — колан, кәҗәнең киеге — коралай.* Мәкаль.

КОРАЛДАШ *и.* Кем белән дә булса солдатта бергә хезмәт итүче яки иткән, сугыш кырында бергә булган кеше; хәрби хезмәттәш. *Һич үкенмәс идем соңы өчен, Коралдашлар исән калсалар.* Г. Хуҗиев. || *с. мәгъ.* Кем белән дә булса бергә хезмәт итүче яки иткән, сугыш кырында бергә булган. *Сәфәргалинең бу солдатка якташ итеп, - - - коралдаш дусы итеп ниндидер җылы сүз әйтәсе килә.* Ф. Хөсни.

КОРАЛДАШЛЫК *и.* Коралдаш булу хәле. *Һәммәбезне бергә кушты Коралдашлык, сафташлык, Бу җиңүгә сез дә, дуслар, Һәммәгез дә катнашты.* Ә. Фәйзи.

КОРАЛЛАНДЫРУ *ф.* 1. Кораллар, хәрби җиһазлар белән тәэмин итү. — *Үткән ел, шулай, беренче майда солдатларны иртә үк коралландырып алып киттеләр.* М. Гафури. *Сталинградта пароходны коралландыру турында приказ алдык.* Х. Садрый.

2. Нинди дә булса эшчәнлек өчен кирәк булган кораллар (2 мәгъ.), материаллар белән тәэмин итү. *Колхозларны яңа техника белән коралландыру.* || *күч.* Белемнәр, мәгълүматлар белән таныштыру, шуларны үзләштерүне тәэмин итү. *Конференция партияне буржуаз-демократик революциянең, үсеп, социалистик революциягә әверелүе өчен көрәш планы белән коралландырды.* КПСС тарихы.

КОРАЛЛАНУ *ф.* 1. Корал, сугыш кирәк-яраклары җитештерү, булдыру; шулар белән тәэмин ителү. *Ашкынып кораллану. Коралланууны кыскарту.* □ *Дошман кулында корал булган кебек, без дә коралланырга, бөтен пролетариатны коралландырырга тиешбез.* Г. Ибраһимов. — *Яхшы коралланган дошман белән сугыш бездән күп корбаннар сорар.* Ш. Усманов. || Сугышка бару, һөҗүм итү яки саклану һ. б. өчен кулга корал тоту, корал алу. *Шулай, эшчем, кораллан, бар сугышка.* М. Җәлил. *Ишектән, сәнәкләр белән коралланган крестьяннарны ияртеп, Биктимер килеп керә.* Т. Гыйззәт. || Өндәү, чакыру тоны белән әйтелгәндә: кулга корал алып, көрәшкә чыгу, күтәрелү. *Кем ирек ди, әйдә, Кораллан!* Х. Туфан.

2. Нинди дә булса эшчәнлек өчен кирәк булган кораллар (2 мәгъ.), материаллар булдыру, шулар белән тәэмин ителү. *Тракторлар белән коралланып, Чыгып китте колхоз чәчүгә.* Ш. Мөдәррис. || Берәр төрле эш башкару өчен кулга нинди дә булса эш коралы алу турында. *Бакчачы карт, - - - саплы пычкы, кәкре пычак белән коралланып, эшкә тотынды.* Ә. Еники.

3. *күч.* Берәр төрле эшчәнлек өчен кирәкле белем, мәгълүмат, сыйфат һ. б.ларны үзләштерү, шуларга ия булу. *Марксизм-ленинизм тәгълиматлары белән кораллану. Техника белән кораллану.* □ *Уку-язу белән коралланган кеше аңлы тормыш кора ала.* М. Гафури. *Син чыдамлылык белән кораллан.* Г. Тукай.

КОРАЛЛЫ *с.* 1. Коралланган, корал белән тәэмин ителгән. *Кораллы өч солдат иярткән, Сәет килеп керде.* И. Туктар. *Безнең отрядта бары җиде кеше кораллы.* Ш. Камал. *Шәһәрнең большевиклар кулына күчүе турында рәсми белдерү чыкканы юк. Ә без кораллы килеш һаман шәһәрне саклыйбыз.* Х. Садрый.

2. Сугыш хәрәкәтләре, бәрелешләр белән үтә торган, кулга корал тотып башкарыла торган. *Кораллы восстание. Кораллы бәрелеш.* □ [*Большевиклар үзәгеннән*] *эш ташлау хәрәкәтен кораллы күтәрелешкә әйләндерү планы бирелгән.* Г. Ибраһимов.

Кораллы көч(ләр) — армия, гаскәр. *Советлар Союзының кораллы көчләре.* □ *Камилгә бу участокта дошманга каршы куелган безнең кораллы көчләребез бик аз сыман тоела иде.* М. Әмир.

КОРАЛСЫЗЛАНДЫРУ *ф.* 1. Кемнең дә булса коралын көчләп алу, ташлату, коралсыз калдыру. *Поручик Мәсгут, ике рота белән, юнкерларны коралсызландыра.* Ш. Усманов. || Кемнең дә булса кораллану мөмкинлекләрен кимәтү, кыскарту яки бөтенләй коралсыз калдыру. *Коралсызландыру комитеты.* || Нәрсәнең дә булса (мәсәлән, хәрби нигытмалар, суднолар) карамагындагы коралларны алып кую, кораллану средстволарыннан мәхрүм итү.

2. *күч.* Кемнеңдер нәрсә өчен дә булса көрәшү мөмкинлеген юкка чыгару, көрәшкә булган омтылышын бетерү.

КОРАЛЧЫ *и.* Корал ясаучы (эшче, мастер). *Коралчылар шәһәр бистәсендә Көн-төн эшләп корал коялар.* Г. Хуҗиев.

КОРАЛ-ЯРАК *и. сөйл.* Һәртөрле кораллар. *Бу, чынлап та, корал-ярак төзәтүче оста, - - - җор сүзле Ваня Рябчиков иде.* Каз. утл.

КОРАМА *и. сөйл.* 1. Файдаланудан артып калган кисентек, вак кисәк (тукыма, тире, такта һ. б. ш. әйберләрнең). *Стена буена төрле корамалардан теркәп тегелгән тар гына юрган сыман нәрсә җәелгән иде.* М. Гафури. *Төрле төстәге корамадан сугылган киндер палас ишек төбеннән түр тәрәзәсенә кадәр сузылган.* И. Туктар. || *с. мәгъ.* Шундый кисәкләрдән

тегелгән, эшләнгән. [*Мәфтуха сәкегә*], *стенага таба терәп, тар корама юрганнар япты.* Г. Ибраһимов.

2. Шундый кисәкләрдән тегелгән җәймә, япма. *Хәсри карчык сандык өстенә җәелгән кораманы алып дүрткә бөкләде.* Г. Гали.

3. Кечкенә, вак-төяк материалдан ясалган корылма (өй, киоск, лапас, ларёк һ. б). *Гаряфи ул заманда базар чатында бәләкәй генә корама астында җептасма, беләзек-балдак, сабын-тарак кебек нәрсәләр белән сату итә иде.* Э. Касыймов. *Бер почмактагы өстәл сыман бер такта корамадан башка мебель рәтенә кертерлек берни юк иде.* Н. Фәттах.

4. *с. мәгъ. күч.* Таркау, ник берләшмәгән. *1918 елның октябренда Австрия-Венгриядә революция башланды.* [*Һәм*] *бу „корама империя“ җимерелде.* СССР тарихы.

5. *с. мәгъ. күч.* Чит тел элементлары белән чуарланган (телнең саф булмавына ишарә итеп әйтелә). *Корама тел.* □ *Мин* [*Зөбәрҗәткә*] *бөтен шикшөбһәләремне, --- әле шушы көннәрдә генә физика укытучысына әйләнүемне, татарчамның да шактый корама булуын --- сөйләп бирдем.* А. Тимергалин. || Мәгънәсез, бернинди мәгънә белдерми торган. *Санамышларның төрле телдән алынган корама сүзләрдән торганнары да аз түгел.* Н. Исәнбәт.

КОРАМАЛАУ *ф.* **1.** Кораламаларны бер-берсенә ялгап тегү. *Башымда --- төрле төстәге хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүш.* Г. Тукай.

2. Сыйфат ягына игътибар итмичә, ашыгыч рәвештә вак-төякләрдән оештырып ясау, аннан-моннан гына төзү. *Акбурлы такталардан гына корамаланган вакытлы вокзал --- бүген бигрәк тә иләмсез күренә иде.* Ш. Маннур.

3. *диал.* Каплап, ябып әйләндереп алу. *Димка --- ак киндер белән корамалап куелган куыш янына йөгерде.* Н. Фәттах.

КОРАМАЛЫ *с.* Кораламалардан эшләнгән, тегелгән. *Түргә, кабартылып, аслы-өсле ике мендәр куелган, иске сандык өстенә дә корамалы юрган җәелгән.* Ак юл.

КОРАМТА *и. диал.* Ат җигү дирбияләре. *Фазлый складтан Тимеркүкнең* [*атның*] *яхшы кораматаларын чыгарды.* Х. Госман.

КОРАУ *ф. диал. к.* корамалау. *Корап сырган иске юрган төсле, Чуарланган дөнья картасы.* Н. Арсланов.

КОРАШТЫРУ *ф. сөйл. к.* корамалау (1, 2 мәгъ.). *Кутуй, бик хәтеремдә, тактадан кораштырган өстәлгә терсәкләре белән таянып, бөкрәебрәк утырган.* И. Гази.

КОРАЧ *с. диал.* Калкурак, су ятмый торган. *Авыл урамнарының корач битләренә яшелле-кызыллы каз үләне тибә башлаган.* К. Тинчурин.

КОРБАН I *и.* **1.** Мөселман динендә: суеп, „аллага бүләк ителә“ торган хайван. — *Җибәрегез, җибәр! Сибайның сыры корбанга ярыймы соң!* Г. Иделле.

2. Кемнең яки нәрсәнең дә булса ниндидер теләкләрен канәгатьләндерү өчен, үләргә, газапланырга, нинди дә булса җәбер күрергә тиешле жан иясе. [*Акчарлаклар*] *елга буйлап үзләренә корбан күзәтә-күзәтә очалар.* А. Шамов. *Кар бураны, яңа корбан эзләп, Бөтерелә койма буенда.* М. Җәлил. *Хәйрүш, сайлаган корбанына ияреп, вагонга керде.* М. Хәсәнов.

3. Нинди дә булса зур бәхетсезлек, афәт, сугыш һ. б. аркасында газап чиккән яки һәлак булган кеше. *Сугыш булса — була корбаны.* Һ. Такташ. *Ирек корбаннарын, хөрмәт итеп, һәр ел саен искә алабыз.* М. Гафури. *Сәрбиҗамал ул — буржуа-мещан тормышының корбаны.* М. Гали. || Ниндидер сәбәп аркасында газапланулларга, күңелсезлекләргә дучар булган кеше. — *Мин интрига корбаны гына булдым.* Г. Ибраһимов. *Түгел инде вакытлы, мәгънәсе юк хискә мин корбан.* Г. Тукай.

4. Кем яки нәрсәнең дә булса файдасы өчен яки башкалар бәхете өчен шәхси иминлектән, интереслардан ирекле рәвештә баш тарту, үз-үзеңне куркыныч, һәлакәт астына кую хәле. *Яманның юлдашы булганчы, яхшылыкның корбаны бул.* Мәкаль. [*Үз эсәрләрендә Генрих Сенкевич*] *куәтле рухлы, гали ниммәтле, ватаннары өчен һәртөрле корбаннарга хәзер тора торган каһарманнар тудыра.* Ф. Әмирхан.

Корбан ае *иск.* — зөлхиҗә аеның халык телендәге атамасы. **Корбан бәйрәме, корбан гаете** *дини* — мөселманнарда зөлхиҗә аеның унынчы көнендә корбан чалып үткәрелә торган дини бәйрәм. *Корбан бәйрәме җитеп, ул да үтте.* Г. Тукай. — *Менә бервакыт, бөтен авылны күтәреп, корбан гаетенә баргандагы кебек тәкбир әйтергә керештеләр.* Г. Ибраһимов.

◇ **Корбан итү** — 1) кем яки нәрсәнең дә булса хакына үзен кызганмау, үлем куркынычы астына кую, һәлак итү. *Батыр егет корбан итә үзен Халкы яшәсен өчен.* Ф. Кәрим; 2) кем яки нәрсәнең дә булса хакына нәрсәдән дә булса баш тарту, нәрсәне дә булса кызганмау, сарыф итү. *Бер төн корбан итеп язылган бу озын гаризада ул үзен очучылар мәктәбенә җибәрүләрен сораган иде.* Р. Төхфәтуллин; 3) оттыру, бирү (шахмат уенында). *Ул унынчы йөрештә бер пешкасын, ә тагын өч йөрештән соң атын корбан итте.* Соц. Тат.

КОРБАН II: **корбан балыгы** *зоол.* — карплар семьялыгыннан төче суларда яши торган яссы тәнле кин балык; *русчасы:* лещ. *Тыны-көне бетеп, кулына шактый зур корбан балыгы тоткан Хәсән килеп чыкты.* М. Әмир.

КОРБАНЛЫК *и.* Корбанга I (1 мәгъ.) билгеләнгән мал. [*Габдрахман:*] *Ничә корбан чалдыгыз? Корбанлыклар симез чыктылармы?* Ф. Әмирхан.

КОРГАК *с. диал.* **1.** Кипкән, кибә торган. *Коргак елга.* || Яңгырсыз, коры. *Коргак ел.*

2. *и. мәгъ.* Коры һава. *Сабанчы яңгыр тели, юлаучы — коргак.* Мәкаль.

КОРГАКСУ *ф.* **1.** Кибү, кипшенү. *Кисмәк коргаксу.* □ *Күпернең коргаксыган вак такталары аяк астында дыбыр-дыбыр итеп калдылар.* И. Гази. *Минһаж аңа* [*этисенә*] *армиядән таянып кайткан таякларын төшереп бирде. Өй чормасында алар бик коргаксыганнар.* М. Шәрифуллин.

2. *күч. сөйл.* Бушап калу, бик ник кимү, ярлылану. *Марат әйткән матур шәл артыннан бик күп нәрсә азык-төлеккә алмаштырылган, сандык төбе тәмам коргаксыган иде.* Г. Гобәй. || Рухи ярлылану. [*Александров:*] *Тракторчыларга мәгънәви азык бер дә бирмисез икән. Егетләр шактый коргаксыганнар.* Ф. Хөсни.

КОРГАКСЫК *с. диал.* Коры, дымсыз. *Җире — коргаксык, кулы — коры капчык.* Мәкаль.

КОРГАКСЫЛ *с. сөйл.* **1.** Ярым кипкән; дымы бик аз калган.

2. *күч.* Бик ябык, чандыр (кеше турында). — *Харченко, — дип, Гыймал ишетелер-ишетелмәс йомшак кына кычкырды. Урман арасыннан коргаксыл гәүдә чыгып, Раяның кулын кысты.* Т. Госман.

КОРГАКСЫТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* коргаксу.

2. *күч.* Кимчелекле итү, йомшарту. [*Әсәрдәге кайбер детальләр эчтәлек*] *бөтенлеге өчен бернәрсә дә өстәмәгәннәр, киресенчә, хикәяне бераз коргаксыта, андагы агитация элементларын ялангачландыра төшкәннәр.* Г. Нигъмәти.

КОРГАУ *ф. иск.* Яклау, саклау, кайгырту. *Тургай, яңгыр яуса, баласын коргый.* Мәкаль.

КОРД *и. махс.* 1. Киже-мамыктан катып эшләнгән бик нык җеп (химик юл белән махсус тукымалар, автомобиль һ. б. өчен шиннар хәзерләүгә китә). || *с. мәгъ.* Шундый җептән эшләнгән, тукылган. *Ясалма сүс комбинатында бик чыдам корд тукыма эшләп чыгару башланды.* Соц. Тат.

2. Йон тукыманың сырлы бизәк белән эшләнгән төре.

КОРДА *и. махс.* Чабышкы яки юртак атларны түгәрәктә йөртеп өйрәтү өчен кулланыла торган озын тезген.

КОРДАШ *и.* Кем белән дә булса яшь ягыннан бер чамада яки бер елгы булып, бергә үскән, бер чорда яшәгән кеше. *Юрга мәңгән—юлдашыннан аерылыр, Күп яшәгән — кордашыннан аерылыр.* Мәкаль. *Кордашларның күбесе һәлак булды, д без әле менә — исәннәр.* Х. Туфан.

КОРДАШЛЫК *и.* Кордаш булу хәле.

КОРДЕБАЛЕТ *и. махс.* Төркемле танецлар башкаручы балет артистлары коллективы. *Татар дәүләт опера һәм балет театры кордебалеты.* □ *Тамаша башланды. Идел буена пикникка төшкән яшьләрне уйнаучы кордебалет Хәбиргә җансыз булып күренде.* Ш. Хөсәенов.

КОРДОН *и.* 1. Юлны саклап торучылар яки чик сакчылары отряды. *Полиция кордоны.*

2. Чик буе сакчылары, урман каравылчылары һ. б. торган, яшәгән урын. — *Әле күптән түгел партизаннар, кичен, урмандагы мин яшәгән кордонга җыелдылар.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Нинди дә булса эшчәнлеккә, хәрәкәткә каршы куелган чара; тоткарлык, комачау. *Себер, сөргән, палач кордоннары аша Киң мәйданга эшче Петров килеп баса.* М. Садри. *Ирек килде, шатлык килде, Кордоннарны җимереп мәңгегә.* М. Максуд.

КОРЕЙ *и. сөйл. к.* кореялы. *Безгә каршы бик сылу бер корей кызы чыкты.* Г. Әпсәләмов.

КОРЕЙЧА *рәв.* Корея телендә. *Корейча сөйләшү.*

КОРЕЯЛЫ *и.* Кореяда яшәүче халыкларның зур күпчелеген тәшкил иткән милләт кешесе. *Корал алды кореялы, --- Китте явыз дошманнардан Туган җирен сакларга.* З. Мансур.

КОРЕШОК *и.* Квитанция кенәгәләрендә битнең квитанцияне ертып, кисеп алганнан соң калган өлеше, төбе.

КОРЗИН *и.* Нәрсә дә булса салып саклау яки күтәреп йөртү өчен чыбыктан, камыштан һ. б. ш. төрле зурлыкта һәм формада үреп эшләнә торган савыт. *Мәрфуга корзиннан зур гына төенчек алып Габдуллага бирә.* Һ. Такташ. *Кече яшендә әтисе --- аңа корзиннар үрергә өйрәткән иде.* А. Расих.

◇ **Корзинга озату** — яраксызга чыгару, ташлау. *Бер яктан, хикәягә кытлык дип тавыш күтәргәндә, икенче яктан, „Янәшә“ кебек хикәяләрне корзинга озату — бу әдәби иҗатка карата хуҗаларча эш итә белмәү түгелме?* М. Әмир.

КОРЗИНКА *и. к.* корзин. *Миңсылу, ашыгып-ашыгып, түгелгән җиләкләрен корзинкасына тутыра.* М. Фәйзи.

КОРИАНДР *и. бот.* Зонт чәчәкләләр семьялыгыннан эфир майлы берьеллык үлән үсемлек. *Кориандр мае.*

КОРИДОР *и.* Бинаның яки квартираның эчендә бер үк этаждагы аерым бүлекләрен яки бүлмәләрен тоташтыра торган озын тар аралык. *Алар зур мәктәпнең озын коридорына килеп керделәр.* А. Әхмәт. *Дускаев аны коридорда, бүлмә ишеге төбендә каршы алды.* Ә. Еники. || Ике яктан нәрсә белән дә булса чикләнгән, киртәләнгән озын тар юл, үтем. *Машиналар паркын узуга, тайга коридоры башланды. Ул, аз гына борылыш ясап, тау ягына таба сузылган.* Ә. Маликов. *Часть әле бөтенләй үк чолганышта түгел, алар янына керер өчен буе ун, киңлеге бер ярым километр коридор калган.* С. Баттал.

Коридор системасы — бинада барлык бүлекләрнең, бүлмәләрнең ишекләре бер гомуми коридорга чыгышлы итеп урнашкан булу. [*Мал фермасының абзарлары*], *--- бер башыннан икенче башына көчкә күренерлек итеп, коридор системасы белән эшләнгәннәр.* М. Гали.

КОРИ'НКА *и. бот.* Төшсез вак кара йөзем.

КОРИФЕЙ *и.* 1. Борынгы грек трагедияләрендә хор җитәкчесе.

2. *кит.* Берәр өлкәдә зур эш күрсәткән бөек эшлекле. *Марксизм-ленинизм корифейлары. Фән корифее.* □ *Хәсән Туфан, ихтимал, әсәрләрен хаклы рәвештә Тукай, Такташ, Җәлил кебек татар поэзиясе корифейлары иҗаты белән рәттән куярга мөмкин булган хәзерге шагыйрьләребезнең иң зурысыдыр.* Р. Мостафин.

КОРК-КОРК *аваз ияр. сөйл. к.* корык-корык. *Чирле иде ул, корк-корк йөткерә.* Г. Ахунов.

КОР-КОР *аваз ияр.* Ана күркә, торна, кара кош һ. б. кайбер ерткыч кошлар кычкырган тавышларны белдерә.

КОРКЫЛДАУ *ф.* „Кор-кор“ дигән аваз, кычкырыклар чыгару. || *күч. гади с.* Лыгырдау, кызыл сүзләр сөйләп маташу. *Шома дуңгыз баласы шикелле, баштанаяк ялтыраган килеш коркылдап торган әллә кемнәрдән „куркаклар, лодырьлар“ исемен ишет! Ух! Нихәтле күңелгә авыр.* Ш. Камал.

КОРМА I *с. сөйл.* Кем яки нәрсә белән дә булса бер чамада, бер иш булган; тиң. [*Бикмулла:*] *Ни барысы унбер атым бар, аның да яртысы үзем белән бер корма.* Г. Бәширов. *Шулай бер көн Миңсылу, тагын байтак үзебез шикелле бер корма вак кызлар җыелыштык.* Г. Лотфи.

-КОРМА II Кушма сүзләрдә „корылма“ мәгънәсендәге икенче кисәк, мәсәлән: **янкорма, өскорма.**

КОРМАЛАУ *с. диал.* Әйләндереп урап алу. *Яулык-яулык болытлар көньяк күген кормалап бетергән.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КОРНЕТ I *и. махс.* Революциягә кадәрге рус армиясендә: атлы һәм чик буе гаскәрләрендә иң түбән офицер дәрәҗәсе (җәяүле гаскәрдә подпоручикка туры килә); шул дәрәҗәдәге офицер.

КОРНЕТ II *и. муз.* Көтүче быргысына охшаш тынлы җиз уен коралы. *Колакка корнетта уйналган „Катюша“ яңгырады.* Х. Мөҗәй.

КОРНЕТЧЫ *и. муз.* Корнетта уйнаучы музыкант.

КОРОЛЕ'ВА *и.* 1. Хатын-кыз король. || *сөйл.* Үзенең матурлыгы, буй-сыны белән аерылып торган хатын-кыз турында. *Тәхеттә безнең королевабыз Гөлнур ханым утыра.* К. Нәҗми.

2. Король хатыны.

3. Шахмат уенында иң көчле фигура саналган ферзьнең икенче төрле атамасы.

4. *күч.* Берәр өлкәдә, даирәдә үзенең уңай сыйфаты белән бик нык аерылып торган зат турында мактап әйтелә. *Матурлык королевасы.* □ *Пехота ул — сугыш кыры королевасы.* Р. Ишморат.

КОРОЛЬ *и.* 1. Кайбер феодаль һәм буржуаз дәүләтләрдә монарх титулы; шул титулны алган кеше. || *күч.* Промышленность яки сәүдәнең бер өлкәсен үз кулында тота торган эре капиталист, монополист. *Финанс короле.* □ *Нефть! Менә бүгенге буржуаз мәмләкәтләрнең бөтен тышкы сәясәтләренең [стимулы], нефть корольләренең табышлары.* Ф. Әмирхан. || *күч. сөйл.* Башкалар арасында матурлыгы, сә-

ләтлелеге һ. б. яхшы яклары белән кискен аерылып торган кеше турында. *Шахмат короле.* □ *Рәфгать— футбол короле.* Б. Камалов.

2. Башына таҗ кигән сакаллы ир кеше сурәте төшерелгән уен картасы. *Карга король. Король белән йөрү.* □ [*Хәлил, картаны бәреп:*] *Тузыңны бир!* [*Садри:*] *Короле бар, шаярма!* Ш. Камал.

3. Шахмат уенында төп фигура. [*Вәли:*] *Бер генә ход, аннан соң корольгә шах, Раузага мат була.* А. Алиш.

КОРОЛЬЛЕК *и.* 1. Башында монарх торган король власте. *IX—XI гасырларда Франция корольлегендә власть әре феодаллар—герцоглар һәм графлар кулында булган.* Урта гас. тарихы.

2. Король вазифасы, хезмәте. *Корольлектән баш тарту.*

Корольлек итү — король булып тору; король вазифасын, хезмәтен үтәү.

КОРО'НКА *и. анат.* 1. Тешнең тышкы катлавы. *Тешләр коронкадан, муентыктан һәм тамырдан торалар.* Анатомия.

2. Бозыла башлаган тешне саклау өчен кидерелә торган металл яки пластмасс тышча. *Тешкә коронка куйдыру.* □ *Бу юлы* [*егетне*] *таза теш өстенә алтын коронка кидереп йөрүче бер кызның сихерле күз карашы тәкатьсез итте.* М. Әмир.

КОРПОРА'ЦИЯ *и.* Тар профессия яки сословие һ. б. ш. интереслардан чыгып берләшкән кешеләр төркеме; шундый төркемнән торган берләшмә, союз. *Нефть корпорацияләре.* □ *Мәдрәсәләрне шулар* [*Казан муллалары*] *корпорациясенә тапшыру ислахны артка гына калдырачак.* Ф. Әмирхан.

КО'РПУС *и.* 1. Бер тирәгә салынган берничә зур бинаның берсе; шулай ук бинаның аерылып торган зур бер өлеше. *Фабрика корпуслары. Ян корпус.* □ *Балалар шәһәре --- агачлар арасына таралып утырган 3—4 катлы корпуслардан гыйбарәт иде.* Ш. Усманов.

2. Нәрсәнең дә булса нигезен яки механизмнар, приборлар һәм аппаратларның тышчасын тәшкил иткән деталь. *Сәгать корпусы.*

3. Судноның бөтен тышкы тышчасын тәшкил иткән өлеше, каркас. [*Су асты көймәсенең*] *кыярга охшаган озын корпусы бер өскә калка, бер дулкын астында югала.* Г. Әпсәләмов.

4. Берничә дивизиядән яки бригададан торган зур гаскәри берләшмә. *Атлы корпус. Корпус командиры.* □ *Корпус штабы аркылы --- дивизия белән дә әлемтәгә кердек.* Каз. утл.

5. Белгечлеге, рәсми яки хезмәттәге дәрәҗәсе белән бердәй кешеләр төркеме. *Офицерлар корпусы.* □ [*Прес-конференциядә*] *журналистлар, дипломатлар корпусы, күренекле галимнәр --- булды.* М. Максуд.

6. Патша Россиясендәге ябык хәрби урта мәктәпләрнең атамасы составында кулланыла. *Кадетский корпус.*

7. *махс.* Типография эшендә: 10 пункт үлчәвендәге хәреф.

КОРПУ'СКУЛА *и. физ.* Материя кисәкчеге.

КОРПУСКУЛЯР *с. физ.* Корпускулалардан торган; корпускулага бәйләнешле. *Кояшның корпускуляр нурланышы. Корпускуляр агым.*

КОРРЕКТИВ *и. кит.* Өлешчә төзәтмә, үзгәреш. *Аппаратураның да кайбер узелларына коррективлар кертергә --- туры килер.* Г. Иделле.

КОРРЕКТИРЛАУ *ф. кит.* 1. Коррективлар кертү, өлешчә төзәтү, үзгәртү.

2. Корректировка ясау, юнәлеш бирү. *Менә самолет очу полосасына керә. Очучының хәрәкәтен җирдән корректирлап торалар.* Соц. Тат.

КОРРЕКТИРО'ВКА *и. хәрби.* Каян да булса күзәтеп, артиллерия утының юнәлешен дөресләү өчен кертелә торган төзәтмәләр яки үзгәртүләр. *Елга буендагы өйләрне артиллерия утына корректировка бирү өчен күзәтү пунктлары иттек.* Каз. утл.

КОРРЕКТИРО'ВЩИК *и.* Корректировка ясап торучы кеше. *Хәсән һәрбер үтелгән километр саен бу кешенең немец корректировщигы икәненә ышана бара иде.* А. Расих.

КОРРЕ'КТЛЫ *с.* Әдәпле, нәзакәтле. | *рәв. мәгъ.* *Үзен корректлы тоту.*

КОРРЕ'КТЛЫЛЫК *и.* Корректлы булу сыйфаты.

КОРРЕ'КТОР *и. махс.* Корректураны уку һәм төзәтү белән шөгыльләнүче типография яки нәшрият хезмәткәре. *Хәзер инде китапны Тагын бер-ике тапкыр Укып чыгарга тиеш Корректор һәм редактор.* К. Нәҗми.

КОРРЕ'КТОРЛЫК *и.* Корректор вазифасы, хезмәте. *Г. Камалның газетачылык эшендәге хезмәтләре, корректорлыктан һәм гади тәрҗемәчедән башлап, редакторлыкка кадәр барып җитә.* М. Гали.

КОРРЕКТУ'РА *и.* 1. Типографик набордан чыккан оттисктагы хаталарны төзәтү эше. *Ул һәр көн типографиядә сигез сәгатьлек корректура хезмәтеннән калган бөтен вакытын шул дәресләренә бирә.* Г. Ибраһимов.

2. Кулъязма белән чагыштырып төзәтү өчен типографик набордан кайтарылган оттиск. *Корректуралар карыйсым бар иде, шуларны бетермичә урынымнан кузгала алмадым.* Х. Кәрим.

КОРРЕ'КЦИЯ *и.* 1. *махс.* Төзәтү. *Күзнең күрүенә коррекция ясау.*

2. *тех.* Кешенең турыдан-туры катнашыннан башка үлчәү приборларының, идарә итү аппаратларының эш-хәрәкәтенә, эксплуатация шартларының үзгәрүенә карап, төзәтмә кертү.

КОРРЕ'КЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Коррекция ясау. *Планетаара автомат станцияләрнең хәрәкәт итү траекторияләрен коррекцияләү.*

КОРРЕЛЯТИВ *с. кит.* Нәрсә белән дә булса корреляциядә булган. *Коррелятив төшенчәләр.*

КОРРЕЛЯЦИОН *с. кит. к.* корреляцияле. *Корреляцион бәйлелек.*

КОРРЕЛЯ'ЦИЯ *и. кит.* Предметларның, төшенчәләрнең яки күренешләрнең үзара мөнәсәбәте, бәйләнеше.

КОРРЕЛЯ'ЦИЯЛЕ *с. кит.* Нисбәттәш, мөнәсәбәттәш. *Корреляцияле төшенчәләр.*

КОРРЕСПОНДЕНТ *и.* 1. Кем белән дә булса язышып, язма рәвештә хәбәрләшеп торучы кеше. *А. М. Горькийның үз корреспондентларына язган хатлары.*

2. Газета яки башка вакытлы матбугатта басыла торган корреспонденцияләр авторы; урыннан корреспонденцияләр (3 мәгъ.) җибәреп торучы вакытлы матбугат хезмәткәре. *„Правда“ газетасының корреспонденты башта үземне, аннан Солтангәрәй белән икебезне карточкага төшереп алды.* Т. Гыйззәт. *Командиры Баймурзин булган истребительләр частена мин корреспондент буларак бардым.* С. Баттал.

КОРРЕСПОНДЕНТЛЫК *и.* Корреспондент хезмәте, вазифасы.

КОРРЕСПОНДЕ'НЦИЯ *и.* 1. Аерым кешеләр яки учреждениеләр арасында почта аша язышу, хәбәрләшү эше. *Крупская — Ленинның барлык корреспонденциясен алып баручы кеше.* А. Расих.

2. *җый.* Почта аша җибәрелә торган әйберләр (хатлар, телеграммалар, бандерольләр һ. б.). *Корреспонденцияләрне кабул итү.*

3. Корреспондент тарафыннан газетага яки журналга урыннан җибәрелгән хәбәрләр, мәкаләләр. *— Корреспонденциянең авторы әйтелми, — диде Гайкин, ирен кырыен кыймылдатып.* Г. Ахунов.

КОРРО'ЗИЯ *и. махс.* **1.** Тирә-як мохит белән үзара химик реакциягә керү нәтиҗәсендә металларның таркалуы (тутыгып ашалуы). *Коррозиягә бирешми торган металлар.*

2. *геол.* Җил һәм су тәэсирендә тау токымнарының (ашалып, җимерелеп) үзгәрүе.

КОРРУ'ПЦИЯ *и. кит.* Югары хезмәт урынында эшләүче кешеләрнең, җәмәгать эшлеклеләренең акчага сатылучанлыгы; хезмәт урыны хокукларын шәхси байлык туплау максатлары өчен файдаланудан гыйбарәт җинаять. *Коррупциядә гаепләнү.*

КОРСАГАЯКЛЫЛАР *и. зоол.* Моллюскларның бер классы; *к.* әкәм-төкәм.

КОРСАЖ *и.* **1.** Хатын-кызлар күлмәгенең муеннан билгә кадәр булган өлеше.

2. Юбканың каты поясы.

КОРСАК *и.* **1.** Кеше һәм хайваннар тәненең ашказаны, бавыр, эчәкләр, талак һ. б. органнар урнашкан өлеше; эч. *Пляжда халыкның чуты-чамасы юк. Кайсы арка кыздыра, кайсы — корсак.* Г. Мөхәммәтшин. || Гәүдәнең аркага капма-каршы ягы. *Унлап малай --- корсаклары белән идәнгә сузылып яттылар.* М. Гали. [*Караборын*], *җиргә ятып, корсагы өстендә дүдүккә табан шуышып килә башлады.* Һ. Такташ. || *сөйл.* Ашказаны, карын. *Эт корсагына сары май килешмәс.* Мәкаль. *Ул арада төш тә якынлашып килә икән, корсак та үзенекен сорый башлады.* Ф. Хөсни.

2. Кайбер предметларда (мәсәлән: самовар, кибән, мичкә, чан һ. б. да) түгәрәкләнеп кабарып чыгып торган урта бер урын. *Шанның [җиргә] авыр көч белән килеп төшкән як корсагы бераз яньчелә төшкән иде.* Ш. Камал. *Мич башы куышында --- нечкәрәк киндерә белән корсагына тарттырып бәйләп куйган җиз борынлы калай самовар тора.* М. Гали.

3. *куч. сөйл.* Зур корсаклы юан кешегә карата көлеп, мыскыл итеп әйтелә. *Бу корсак [Галиәкбәр агай] үзе, Россиядә торып, русча сөйләшә белми.* Ш. Мөхәммәдев. || *куч. сөйл.* Гадәттә „зур, юан“ сүзләре белән янәшә кулланылып, „бай, аристократ, эксплоататор“ дигән мәгънәдә мыскыллап әйтелә. *Матур булыр бу корсакларга каршы чаралар корсак, Тотып ярсак боларны без, Заман үткәрми, картаймай.* Г. Тукай. *— Патша белән юан корсаклар өчен сугышып йөрер хәлебез юк.* К. Нәҗми.

4. *куч.* Ашау, ашауга булган ихтыяҗ. *Мал өчен, корсак өчен бер-берсенең Борыннарын чәйнәшәләр алар [муллалар, байлар].* Һ. Такташ. *— Бездә корсак кайгысы гына түгел! — диде Нургали агай.* Г. Минский.

5. *сөйл.* Ана карынындагы бала турында; *к.* йөк II. *— Хәзер [Рәүфәнең] корсагы бар.* А. Шамов.

Корсак тифы — югары температура, эч китү һәм көчле баш авырту белән үтә торган йогышлы авыру. *— Берәү тимгелле тиф белән авырган. Хәзердән чарасын күрмәсәң, корсак тифы куркынычы да юк түгел.* М. Әмир.

◇ **Корсак ачу** *диал.* — ашыйсы килү. **Корсак буш** *гади с.* — ач; ашамаган. *Тырышып-тырышып эшләсәк тә, корсагыбыз буш әле.* Г. Коләхметов. *Корсагың буш булса да, күңелең хуш булсын.* Мәкаль. **Корсак киерү** — масаю, һавалану, мактану. *Кулларын артка куеп, корсакларын киереп, [алма байлары] бакчадан бакчага йөрделәр.* И. Гази. **Корсак колы** — ашау, байлык туплау кайгысы белән генә яшәүче. *Кичә милләтче булып янган зыялы — бүген корсак колы.* Г. Ибраһимов. **Корсак күтәрү** — йөккә, балага узу; йөкле булу. *— Хатыннарыбыз корсак күтәргәндә тозлы кәбестә талымласалар, ат җиген, күрше авылларга чабабыз.* М. Әмир. **Корсак симертү** *гади с.* — *к.* корсак үстерү. [*Бу байлар*] *көн-төн бил бөгүче, тир түгүче һөнәрчеләр исәбенә корсак симертәләр.* Каз. утл. **Корсак туйдыру** — 1) ашау, ашауга булган ихтыяҗны канәгатьләндерү; 2) нинди дә булса шөгыль, һөнәрнең кәсеп, яшәү чыганагы була алуы турында. [*Җаббар:*] *Ул музыкаң, ул рәсемең белән ни чыгарасың? Ул --- корсак туйдырамы?* Г. Ибраһимов. **Корсак тутыру** *гади с.* — 1) туйганчы, гарык булганчы ашау; 2) йөклелек срогының соңгы стадиясендә булу (гадәттә ирсез хатыннар турында әйтелә). **Корсак төшерү** — бала төшерү; аборт. [*Тутакай Хаҗиягә:*] *Хаҗи абзый хаҗда чакта җиде корсак төшердең.* Т. Гыйззәт. **Корсак шиңү** *гади с.* — 1) ябыгу. *— Дәй, фәлән бай! --- Корсагың шиңгән, төсең беткән... Ничек булды болай?* М. Гафури; 2) *ирон.* ярлылану. **Корсак үстерү** *гади с.* — 1) симерү, юанаю; 2) баю. *— Туры кәсептән алай кеше корсак үстерә алмый.* Г. Ибраһимов. **Корсакка калу (узу)** — *к.* балага узу. *Кәләш корсакка узды. Көннән-көн юаная башлады.* М. Әмир. **Корсакта бүреләр улау** — бик нык ашыйсы килү. *— Бәлкем, аның корсагында бүреләр улыйдыр.* Э. Касыймов.

КОРСАКЛАНУ *ф.* **1.** *сөйл. шаярт.* Корсакка узу, йөкле булу.

2. *сөйл.* Симерү, корсак үстерү.

3. Корсак төсле кабарып чыгып тору. *Юлның ике ягыннан корсакланып чыккан куе агачлар арасыннан тар гына булып саф зәңгәр күк күренеп тора.* М. Гали.

КОРСАКЛЫ *с. сөйл.* **1.** Корсагы зур, юан. *Менә корсаклы бай ашка барадыр: Атын тоткан; көлеп, авызы ерылган.* Н. Исәнбәт.

2. *к.* йөкле II. [*Хәмидә:*] *Мин үзем бервакытны, Сарадан элекке балама корсаклы вакытымда, бик каты бастырылдым.* Г. Камал.

КОРСАР *и. иск.* **1.** Диңгез юлбасары, пират.

2. Юлбасарлар судносы.

КОРСЕТ *и.* Гәүдәне зифа итеп күрсәтү өчен эчтән тыгыз итеп киелә торган киң пояс. *Хәдичә дә корсетны булдыра алган кадәр ныграк кысты, соңгы модадагы эшләпәсен, --- иң яхшы күлмәген киде.* А. Расих. || Умыртка сөяге авырткан яки көкрәя башлаган вакытта киеп йөри торган каты бандаж. *Култык асларымны чиләндереп, мыш-мыш килә-килә корсет киеп йөргән язны сугыш бетте.* Р. Төхфәтуллин.

КОРТ [корт] I *и.* **1.** Озынча гәүдәсе белән боргаланып яки бер җыерылып, бер сузылып хәрәкәт итә торган умыртксасыз тереклек иясе (яшелчә, җиләк-җимешләрдә һ. б. тереклек итә торган бөҗәкләр); личинка. *Ефәк корты. Кәбестә корты.* □ *Алманың асылын корт ашый.* Мәкаль. *Дөнә кайбер кошлар инде симез кортларны, җилкәләреннән тешләп, ояларында чыр-чу килгән зур авызлы, ялангач башлы чебиләренә ташыйлар.* Ә. Еники.

2. Әлпә канатлылар отрядыннан чәчәк нектары һәм серкә җыеп, нектарыннан бал, серкәсеннән чыршын эшләп чыгара торган бөҗәк; бал корты. *Корт анасы. Корт иле. Эшче кортлар.* □ *Бал тәмле дә, корт чага.* Мәкаль. *Гаяз умартачыга кортлар аерырга булышты.* И. Гази.

3. *куч.* Кеше көче хисабына яшәүче, әрәмтамак, паразит. *— Д син, абзый, үз сүзеңдә Нык бул, таза,*

каты бул, Мондый кулак кортларына Курыкмый отпор бир. М. Җәлил. *Дөньядан кем себерә алтын колларын? --- Кем сала утка капитал кортларын?* Һ. Исәнбәт.

4. *күч. сөйл.* Берәр нәрсә белән артык мавыккан, бик еш шул эш белән мәшгуль булган кешегә карата көлеп яки кимсетеп әйтелә. *Китап корты.* □ *Әй, сез, калдык нәпман уллары! Базар корольләре! --- Череп беткән сыра кортлары!* Һ. Такташ.

5. *күч.* Борчылу, газаплану, шикләнү хисе, хәле турында. *Көнчелек корты.* □ *Иштуган, Илморза авылга китәргә җыена, дип әйткәннән бирле Сөләйман абзыйның йөрәгендә борчылу корты кыймылдарга тотынды.* Г. Әпсәләмов.

Корт юлы — берәр нәрсәдә (яшелчәдә, җиләк-җимештә, агачта) корт, личинка тишеп, ермачлап үткән эз. **Корт төшү** — кортлау. *Җиләк-җимешләргә корт төшү.*

КОРТ [корт] II *и. махс.* Әчегән сөтне әкрен янган утта озак, кызыл төскә кергәнче кайнатудан алынган ашамлык, кызыл эремчек. *Бу якча, кызыл эремчек, безнең якча, тура яки корт дип атала торган азыктан без шушында авыз иттек.* И. Гази. *Зифа карчык --- пыяла савыты белән балын һәм кызыл корт белән аралаштырган маен алып кер[де].* А. Шамов.

КОРТ *и. спорт.* Теннис уены мәйданы.

КОРТАШАР *и. зоол.* Тау чыпчыклары семьялыгыннан зур булмаган кошчык; *русчасы:* щур. *Артыш җиләген --- төньяктан кайткан чәрелдәвек, карабүрек, корташар ярата.* Г. Хәсәнов.

КОРТБАШ *и. этн.* Күз тимәсен дип, кечкенә балаларның башлыгына тагыла торган әкәм-төкәм кабырчыгы. *[Хуҗа Насретдинның] кулында балта, --- башында кортбаш таккан тупый сыман түбәтәй.* Н. Исәнбәт.

КОРТИК *и.* Хәрби Диңгез Флоты адмираллары һәм офицерлары, шулай ук Хәрби һава Флоты генераллары, офицерлары тагып йөри торган кыска хәнҗәр формасындагы салкын корал. *Тоныk ут шәүләсе, көмеш укалы поручик погоннарын, --- сәяк саплы кортикны яктыртып, козырек астындагы яшькелт күзләргә төртелде.* К. Нәҗми.

КОРТКА *и. сөйл. к.* карчык. — *Дбиең кем? Бибисәрия бугай? Намаз укыганда кыйбланы компас белән эзләүче кортка.* Г. Мөхәммәтшин.

КОРТКЫЧ *и.* **1.** Иген, урман, бакча, амбар хуҗалыкларына һәм көнкүреш әйберләренә зарар китерә торган җәнлек, бөҗәк. *Бакча корткычлары.* □ *[Кырмыскалар] урман корткычларына каршы көрәшәләр.* А. Алиш. — *Бик үрчемле корткыч бит ул [әрләк]. Бер карыннан ел әйләнәсенә утыз-кырык әрләк үрчүе мөмкин.* Г. Гобәй. — *Мин аеруча кызыксындым Бүрттереп чәчү белән, Чәчкән җирне корткычлардан Тазарту, әрчү белән.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Зарарлы. *Корткыч бөҗәкләр.* || *күч. сөйл.* Нәрсәгә дә булса зыян ясаучы кеше (гадәттә көлеп, шаярып әйтелә). *Кар бетү белән, Ибрайның иртә шалканнары өлгерә, һәм ул шалканнарның иң куркынычлы корткычлары без була идек.* М. Әмир.

2. Явыз ният белән халыкка, дәүләткә зарар китерә, начарлык эшли торган кеше. *Корткыч кулын суза һәр урынга, һәр кулакның обрез кулында...* Һ. Такташ. | *с. мәгъ. дсәр грузчиклар арасыннан әле сыйнфый аңы үсеп җитмәгән, шунлыктан корткыч сыйнфый дошманга корал булган --- типларны күрсәтә.* М. Җәлил.

КОРТКЫЧЛЫК *и.* Җинаятьчел, зарар китерүгә юнәлтелгән эшчәнлек. — *[Сөләйманов] ферма эшендә ник бер уңай якны күрсен, --- әйтерсең, Нургали фермада бары корткычлык эшләп яткан.* Ә. Еники. *[Гайнуллин], үз тирәсенә Миңниләрне, Гәрәйләрне җыйнап, шпионлыкка, астыртын корткычлыкка хәзерләнде.* Х. Госман.

Корткычлык итү — 1) зарар китерү, зараплау (корткыч бөҗәкләр турында); 2) җинаятьчел, зарар китерүгә юнәлтелгән эшчәнлек алып бару.

КОРТЛАУ *ф.* Әчендә кортлар барлыкка килү, кортлы хәлгә килү. *Ит кортлау.* □ *Өлгергәнче [алманың] --- яртысы кортлап бетәчәк.* И. Гази.

КОРТЛЫ I *с.* **1.** Кортлаган, корт төшкән. *Кортлы алма. Кортлы балык.*

2. *күч. сөйл.* Тиктормас, кыбырсык (кеше турында).

КОРТЛЫ II *с.* Корт II белән аралаштырылган, корт катнаштырылган. *Самовар кайнап чыккач, Нәгыймә чәй әзерләде, кайдандыр алып, кортлы май да китереп куйды.* М. Гафури.

КОРТЛЫГАН *и. бот. к.* аю көпшәсе.

КОРТЧА *и. зоол.* Авыл хуҗалыгы культураларының һәм җимеш агачларының куркынычлы корткычы саналган хортумлы бөҗәк; *русчасы:* червец.

КОРТЧЫ *и. к.* умартачы. *Уң якта кортлар кышлый торган омшанник. Сулда кортчы Апанасның торак бүлмәсе.* Т. Гыйззәт.

КОРТЧЫЛЫК *и. к.* умартачылык. *[Колхозның] умарта караучысы бер кортчылык эшен генә түгел, умартачылык эшенең бөтен техникасын бик яхшы үзләштергән колхозчы икән.* М. Гали. *[Белгеч] колхозчылардан ике кешене кортчылык эшенә өйрәтергә --- вәгъдә бирде.* Г. Бәширов.

КОРУ I *ф.* **1.** Тиешле юешлелеге, дымы бетеп, артык коры хәлгә килү. — *Җир корый, оланнар, җир корый.* К. Тинчурин. || Парга әйләнү, юкка чыгу, кибү (су һ. б. сыеклыклар турында). *Диңгез кебек җәйрәп яткан күлләр дә бер корый икән.* Г. Ибраһимов. *Күкрәккәем сызыла, тәнем яна, Күзләрем дә кыза, яшь корый.* М. Җәлил.

2. Дым җитмәү сәбәпле шинү, тереклек итүдән туктау. *Бернәрсә дә юк монда, хәтта таллар, Ак каеннар корып беткәннәр.* Ә. Ерикәй. *Үләннәр корыган, яфраклар саргайган.* Ш. Камал.

3. *күч.* Ябыгу, саргаю (авыру, үтә авыр эш, рухи газаплар аркасында). *Тарлыктан һәм якты юклыктан Корыган, боекkан идек без.* М. Җәлил. — *[Фатыйма] үзе дә кибеп, корып беткән инде.* Г. Камал.

4. *күч.* Авыру, паралич сугу аркасында тереклек хәлен югалту, хәрәкәтләнүдән туктау (кеше әгъзалары турында). *Аяк кору. Кул кору.*

5. *күч.* Үлеп бетү, юкка чыгу. — *[Минем ирем] бу арада юк-бар сүз белән бик теңкәмә тиеп йөдәтә башлады. --- Ходай бала бирми, ди, нәселебез корый, ди.* Г. Ибраһимов. — *Нәсел-нәсәпләре корсын буржуй-империалистларның!* К. Нәҗми.

6. *күч. сөйл.* Бетү, бетеп китү; әкренләп юкка чыгу. *Байлык кору. Акча кору.* □ *Юк, хикәя корый торган жанр түгел ул!* М. Әмир.

КОРУ II *ф.* **1.** Төзү, салу; торгызу. *Баррикада кору.* □ *Без чит державаларга ялынмыйбыз хәзер, эшче-крестьянның үз көчләре белән яңа завод-фабрикалар корабыз, авыл хуҗалыгын күтәрәбез.* М. Гали. — *Ыргылма суына тегермән корырга йөриләр.* И. Гази. || Ясау, төзү (лагерь, палатка һ. б.). *Крепостной крестьяннарның юлбашчысы Пугачев күпмедер вакыт Бөгелмә тавында лагерь корып торган.* Г. Әпсәләмов. *[Челюскинчылар] брезентлардан палаткалар кордылар, --- фанералардан бараклар эшләделәр.* А. Алиш. || Ясау, эшләү. *Сайрар кошлар җылы яклардан кайтып --- оя кордылар.* Г. Гобәй. *Зәйнәпнең әтисе сәке янына киндер урыны корды.* Дәрдмәнд.

2. Булдыру, барлыкка китерү; төзү, оештыру. *Коммунизм эҗәмгыяте кору.* □ *Җир шарында беренче булып, Без бәхетле, шат тормыш кордык.* Ә. Исхак. [*Закиров*] *үзенең шушы көнгә кадәр әле матур, тату семья кора алмавыннан зарланды.* А. Шамов. *Илдә авыл хуҗалыгын социалистик нигездә яңадан кору чоры башланды.* М. Әмир.

3. Материалны сайлап һәм билгеле бер тәртиптә оештырып, нәрсә дә булса иҗат итү, төзү. *Безнең әдәбиятыбызда булган --- җитешсез якларның [берсе] — әсәрне конкрет бер идея нигезенә кормау.* Г. Халит. || Билгеле бер тәртиптә, системада оештыру, алып бару; җайлау. *Эшне план нигезендә кору.* □ [*Мөхәммәтҗанов*] *ничектер эшне гади һәм ачыктан-ачык сөйләшергә кора белми иде.* А. Расих.

4. Җыю; оештыру, үткәрү (мәҗлес, туй, кичә, уен һ. б.). *Мәҗлес кору.* □ [*Хәким — егетләргә:*] *Нигә тегендә бармыйсыз? Анда без табынны кордык.* М. Фәйзи. *Малайлар, --- вак агачлыклар тирәсенә чыгып, төрлечә уеннар корырга, кош йомыркалары эзләргә керештеләр.* М. Гафури. || *сөйл.* Үткәрү (әңгәмә, җыелыш һ. б.). — [*Нәгыйм*] *минем белән берничә кабат шушы турыда әңгәмә корып маташты.* Ш. Камал.

5. Каплау, ябу, элеп кую. [*Гайсә*], *тәрәзәләрнең берсенә Рабига җиңгинең калын шәлен, икенчесенә юрган корып, әкрен генә ящикны ача башлады.* К. Нәҗми. *Алача чаршау, комач бау, Кор дисәң дә кормамын.* Җыр.

6. Берәр нәрсәгә нигезләү. *Әсәрнең сюжетын көндәлек тормыш материалына кору.* □ [*Галия*], *Рәүф белән танышканнан алып аерылуынача, аңа үзенең мәхәббәтен ялган исәп-хисапка кора.* Г. Нигъмәти. *Юк, хәйләгә кормадым һәм кора белмим һәр хәрәкәт, һәр адым һәм борылышны.* З. Мансур.

7. *күч.* Ясау, оештыру, уйлап чыгару. [*Анисимов:*] *Бернинди дә интрига корган кеше юк, Сәрвәрев. Син пычрак ыргытма!* Р. Ишморат. *Пардәсеннән төннең файдаланып, Сугышчылар хәйлә кордылар: Сиздермичә фланглардан барып, Елга аша чыкмак булдылар.* Ә. Исхак. || Оештыру, сөйләү (гайбәт, ява). — *Гайбәтләр кору бик алама хатыннар гадәте инде ул.* Ш. Камал. || Планлаштыру, эшләү, башкару. [*Кайбер тәрбиячеләрнең*] *балалар арасындагы тәрбия һәм башка эшләрне үз теләкләренә, үз вакытларына карап корулары нык күзгә ташлана.* Ф. Кәрим. || Төзү, хәзерләү (план турында). *Хәсән үзенең киләчәк эшләренә план кора башлады.* А. Расих.

8. *ярд. ф. функ.* Кайбер абстракт исемнәр белән тезмә фигыль ясап, шул исемнән аңлашылган эшне эшләү, шуның белән мәшгуль булу мәгънәсен аңлата (ягъни шул исемнәрдән фигыль ясый торган кушымчалар функциясен үти, мәсәлән: *гәп кору — гәпләшү, уй кору — уйлау). Ишетә алмадым, нидер сөйләштегез, Шыпырт кына киңәш кордыгыз.* Ш. Маннур. [*Казан университетында*] *укырга дип яшь Горький хыял корган.* Г. Кутуй.

КОРУ III *ф.* **1.** Берәр төрле ату яки шартлаткыч коралга заряд (1 мәгъ.), снаряд, патрон кую. *Без автоматларны корып, сак адымнар белән, тавыштынсыз гына алга барабыз.* Ә. Айдар. *Безнең егет бак астына Шартлаткыч кора.* Ф. Кәрим.

2. Нәрсәне дә булса көйләү, берәр төрле эш башкарырга хәзерлек хәленә китерү. *Фотоаппаратны кору. Утсүндергечне кору. Радионы кыска дулкынга кору.* □ *Мин барганда сепараторны кормаганнар иде.* Г. Галиев. || Аулау, тоту өчен нинди дә булса җайланманы көйләп кую. *Имән агач төбендә тозак кордым төлкегә.* Җыр. *Аулар корып, кулга эләктерде [сандугачны] усал аучы.* М. Гафури.

3. Электр энергиясе туплау (берәр төрле приборда һ. б.). *Аккумуляторны кору. Батареяны кору.*

КОРУЛЫ I *с.* Корылган, корып куелган (чаршау, пәрдә һ. б. турында). [*Хөснуллаларның*] *тәрәзәләре корулы, утлары ялтырап яна иде.* Ш. Камал.

КОРУЛЫ II *с.* Корылган, заряд куелган (ату кораллары турында). *Корулы мина. Корулы туп. Корулы мылтык.*

КОРЧАҢГЫ *и.* **1.** Корчаңгы бетенең (талпанының) кеше яки хайван тиресенә үтеп керүе сәбәпле, тәндә куыклы тимгелләр һәм кымыржу, кычыту барлыкка килү белән үтә торган йогышлы тире авыруы. [*Гали Байбикәгә:*] — *Әнә, бабай кашына башлады. — Әллә корчаңгы басканмы үзен?* Д. Аппакова. *Шәйхаттар бабай, --- тырышып, атның корчаңгысын дәвалады.* Г. Гобәй. || Шундый авыруы булган кеше. *Кем кайгысы нәрсәдә, корчаңгының — мунчада.* Мәкальләр. || *с. мәгъ.* Корчаңгы белән авырый торган. *Корчаңгы атлар таза атлар белән бергә торганнар.* А. Алиш.

2. *күч. гади. с.* Юньсез, әшәке. — *Ах, корчаңгы, корчаңгы! Шул башы белән кыз сөйгән булып, кызлардан хат алган булып маташа бит, э!* Г. Камал.

Корчаңгы бете (талпаны) *зоол.* — кеше һәм хайван тәнендә корчаңгы авыруы барлыкка китерә торган паразит бөҗәк.

◇ **Корчаңгы тел** *гади с.* — телчән, күп сөйләргә яратучы кеше турында.

КОРЧУ *с. диал.* Вакчыл, бәйләнчек. *Холыксыз карт корчу булыр.* Мәкальләр.

КОРШАЛУ *ф. Төш. юн. к.* коршау II. *Шактый вакытлар барып, урманның агачлар белән коршалган юлларын тарсына башлаганда, инде без урманнан чыгарга якынлашкан идек.* Ф. Әмирхан. *Зират биек үр өстендә. Аның әйләнә-тирәсе кыргый ташлар белән коршалган булган.* И. Салахов.

КОРШАУ I *и.* **1.** Юка нечкә агач яки металлдан бөгеп эшләнгән бөҗра (мичкәләргә, кисмәкләргә, арба тәгәрмәчләренә кидереп ныгытыла). *Бер төркем --- коршаулары таралган мичкәләр --- тирәсендә, акрын гына уен-көлке сөйләшеп, тәмәке тарта.* М. Галәү. [*Габдрахман*] *Равилне һаман --- коршау тәгәрәтеп йөрүче малай итеп күз алдына китерә иде.* А. Расих.

2. *күч.* Богау мәгънәсендә. *Богауларны киертергә, Теләгәнчә биетергә Уйлаган шаһлар Киде үзләре коршаулар.* Г. Камал.

◇ **Коршау ату** — 1) кисмәк яки мичкә бүртеп, агач коршау ычкынып китү; 2) *иск.* бөлү, банкротлыкка чыгу. *Мотыйгулла коршау аткан елнымы, --- Москвада шул корсак Галиәкбәр бай белән әлгеп китеп, адәм рисвае булып кайткан идем.* Ш. Мөхәммәдев. **Коршау сугу (тарту)** — коршаулау. *Кисмәккә коршау тарту.* □ *Без эти белән тәгәрмәчләргә коршау сугып маташабыз.* М. Шәрифуллин. **Коршау сугып йөрү** — булмастай, мәгънәсез эш артыннан йөрү. *„Диңгез юлын коршап җиңәрбез!" дип, Коршау сугып йөри крейсер.* Х. Туфан.

КОРШАУ II *ф.* Нәрсә белән дә булса тирәләп, әйләндереп чолгап алу. *Өй янында чебиләр өчен, иске читәннәр белән коршап, ялан ясадык.* Ә. Айдар. *Калын имән урманнары авылны тирә-яктан коршап алган булган.* М. Галәү.

КОРШАУЛАУ *ф.* **1.** Коршау кидерү, коршау белән әйләндереп ныгыту (мәсәлән, тәгәрмәчне, кисмәкне).

2. *диал. к.* коршау II. [*Мәйсәрә*] *йон яулыкның чуклары белән әз генә алсуланган битен коршаулап бәйләгән.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КОРШАУЛЫ *с. диал.* Корулы, бүлеп алынган. *Кровать алды чаршау белән генә коршаулы иде.* Ш. Камал.

КОРЪӘН *и.* Мөселман дине кануннарын эченә алган һәм шуларны аңлаткан, „изге“ саналган китап. *Мулла Гайфетдин әфәндe Ижбулдин, коръәннән дәлилләр китереп, мөселман гаскәриләрен әдәпле, тәртипле булырга димләде.* К. Нәҗми. — *Ялган, хәзрәт, валлаһи ялган, хәзрәт, валлаһи ялган. Коръән алып ант итәм.* Т. Гыйззәт.

Коръән чыгу (уку) *дини* — дини йола буенча: кемнең дә булса авыруын дәвалау яки гөнаһларын ярлыкау, бетерү йөзеннән берәр руханиның коръәнне тулысынча укып чыгуы. — *Галимә балам, тыныч ят... Болар сине коръән чыгып өшкерергә генә килгәннәр.* М. Гафури. *Хәзрәт коръән укып җибәрде.* Г. Әпсәләмов.

КОРЫ *с.* **1.** Юешләнмәгән, чыланмаган, суланмаган. [*Илсөяр*] *каршы як ярга чыккач, чирәмдә яткан килеш, коры киемнәрен юеш тәненә киде.* Г. Гобәй. || Дым тартмаган, дымыкмаган. [*Бай*] *„йоның коры түгел, юеш“ дип,* [*йон*] *сатучыны кысып, җәберләп, хакын киметә.* Ш. Мөхәммәдев. || Юеш (дымлы) түгел, составында су парлары бик аз булган (һава турында). — *Менә шушы бүлмә бирелә, туганкай, бик җылы һәм коры була.* Ф. Әмирхан. || Юеш, пычрак түгел (җир, туфрак). — *Иртәгә үк кайтам, — дип карар итте Якуб, — аяк асты коры, ара якын.* И. Гази. *Тау башында, коры җирдә, елан буламы?* Т. Гыйззәт.

2. Явымсыз, яңгырсыз; аяз, кояшлы (һава торышы турында). — *Коры һава шартларында уракны мөмкин кадәр тизрәк бетермичә һич ярамый.* Ш. Камал. —*Дәүләт йөкләмәләрен коры чакта үтәү безнең өчен яхшы.* Р. Ишморат. | *рәв. мәгъ. Урамнарның чамасыз пычрак икәнен, көннәр коры торуга карамастан, күл-күл сулар җәелеп ятуын үзләре дә күрәләр иде.* Г. Әпсәләмов. || Кышын була торган ачы, зыкы салкын турында. *Коры суык шәкертләрнең битләрен, колакларын чеметтерде.* Г. Ибраһимов. *Бигрәк коры, тәрлек туңа.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

3. Үсүдән, яшәүдән туктаган, яфраклары коелып, яшеллеге беткән, корыган (үсемлек турында). *Менә шул вакытта кайдадыр коры чыбыклар шытырдадылар.* К. Нәҗми. *Өч кеше чокыр әчләп аска, елга буена төштеләр дә үткән елгы коры камышлар эченә кереп югалдылар.* И. Гази. || Булган үз дымы да кояш яки ут җылысында кибеп беткән; *киресе:* чи. *Коры утын белән чи дә яна.* Мәкаль. — *Син утны карый тор, мин корырак агачлар җыйнап килим әле.* Ф. Бурнаш. || Өлгереп җиткән (орлык, ашлык, иген). — *Бодайның чынлап торып өлгерүе кичәлебүгенле генә бит. Ә корткычка* [*йомранга*] *иң өлгергәне, иң корысы кирәк. Туклыклы да була, үрми дә.* Г. Гобәй.

4. *и. мәгъ. к.* коры җир. ***Ут ачыйк дошманнар явына Корыдан, диңгездән, һавадан!*** М. Җәлил. *Халыкның бер өлеше тиз-тиз генә көймәне корыга сөйри башладылар.* Ш. Камал.

5. *күч.* Буш, бернәрсә дә салмаган, бернәрсәсе дә булмаган. *Коры кесә. Коры капчык.* □ *Флягалар инде коры, Нишләргә соң, нишләргә?* Н. Дәүли. *Ат коры арбаны да тартып бара алмый.* М. Гафури. || *рәв. мәгъ.* Буш, бернәрсәсез. *Гүргә кергән кире чыкмас, өйгә кергән коры чыкмас.* Мәкаль.

6. *күч.* Берни дә җәелмәгән, түшәлмәгән, шәрә. *Сәкедә әнисе — җәйгән урында, әтисе, чишенмичә, коры сәкегә сузылып, йоклыйлар.* Ф. Кәрим. — *Бу киезне дә алып, ул коры тактада ятсынмыни инде?* М. Фәйзи.

7. *күч.* Буш, сүздә генә калып, тормышка, гамәлгә ашырылмаган; нәтиҗәсез, файдасыз. *Кызганырлык яклары бар аның барын. Тик бу коры кызганудан кемгә нинди файда?* Г. Бәширов. *Ул „бүген-иртәгә җибәрербез“ дигән коры вәгъдәдән башка һичбер җавап ала алмады.* М. Гали. || Дәлилсез. *Башкалар, булмас, Садыйк алай эшләмәс, дигән коры сүз белән калдылар.* Г. Нигъмәти. || Законлы рәвештә бер-берсенә бәйләнгән күренеш яки предметларның берсе, башкалардан аерып алынганы (*гына* чикләү кисәкчәсе мәгънәсендә). — *Җире булмагач, аның коры иреге белән нишлик?* Т. Гыйззәт. *Нәрсә чыксын коры протесттан, Ачлык походлары ясаудан.* М. Гафури.

8. *күч.* Калориясе, туклыклылыгы булмаган, дирбиясе җитмәгән (итсез, майсыз аш-су турында). *Иртә белән дә коры икмәк белән чәй генә эчтеләр.* Ан. *Һәркайсы коры чәген, итсез бәрәңгесен тыныч кына ашап-эчеп ятачак.* Ә. Еники.

9. *күч.* Гади, гадәти. *Быелга кадәр Михаилның Хәятка мөнәсәбәте коры дуслык кына иде.* Ф. Әмирхан. *„Мужик йокысы“ шигыренең, оригиналына караганда, артык 28 тезмәне эченә алуы Тукайның биредә дә коры күчерүче генә булып калмавын күрсәтә.* Г. Нигъмәти.

10. *күч.* Таләпчән, каты күңелле, нык тора торган; усал (кеше характеры турында). — *Мин хәзер корырак, дөресрәге, таләпчәнрәк кеше. Эш интересы өчен, миңа якын ипташларемнән дә, хәтта элек үземенең остазым булган кешеләрдән дә җитди эш таләп итәргә туры килә.* Р. Ишморат. || Усал, таләпчән; кырыс, ягымсыз (тавыш, сүз һ. б. турында). *Аның коры һәм каты тавышын Габдулла үзенә кычкырылган боерык шикелле кабул итте.* Ә. Фәйзи. || Йөрәк хисенә бәйләнмәгән, җансыз, салкын; рәсми. [*Нәфисә*] *Зиннәткә коры бер караш ташлап, алга төшкән чәч толымнарын аркасына чөеп җибәрде.* Г. Бәширов. | *рәв. мәгъ. „Без белешмәсәк тә, белешүче табылган әле“, — диде дә үзе коры гына елмайды.* Ф. Әмирхан.

11. Художестволы түгел, сурәтләү чараларына ярлы, җансыз. *Әсәрдә күп кенә персонажларның теле коры, декларатив.* М. Җәлил. | *рәв. мәгъ. Бу хәбәр болай басарга ярарлык, тик, Шакиров әйтмешли, бераз корырак язылган иде.* Г. Минский.

Коры боз — углеродның икеле окисе (CO_2), углекислый газның басым белән каты хәлгә китерелгән төре. *План бик иркен итеп төзелгән: икмәк заводы, коры бозда эшләячәк сөт заводы, гигант холодильник... — барысы искә алынган һәм бик вәземләп язылган иде.* Г. Ахунов. **Коры елга (чокыр)** — элек суы булып та, хәзер кипкән елга урыны; елга үзәне. *Ул, күпергә бара торган олы юлны ташлап, сулга борылып керде һәм, коры елгалар, куаклыклар аша барып, ярдан су читенә шуышып төште.* Г. Гобәй. *Коры чокырның ары ягында Газинур күренде.* Г. Әпсәләмов. **Коры сызлау** *сөйл.* — ревматизм авыруы. *Кеше килсә, әйтерсең: мин авырыйм, миндә коры сызлау.* Г. Ибраһимов. **Коры черек** — кишер, чөгендер кебек тамыразыкларда була торган авыру. **Коры җил** — чүл яки дала ягыннан исеп, үсемлекләрне һәлак итә торган кайнар җил; *русчасы:* суховей. *Стена кебек күтәрелеп Яшел урманнар үсә; Басуларга юл табалмас, Коры җил шашып килсә.* Ә. Ерикәй. **Коры җир** — җир өстенең судан (океан, диңгез, күл, елгадан) башка өлеше. *Әллә инде биш тәүлек буе су өстендә килеп тә коры җиргә аяк басуданмы, — эшне кайдан тотып башларга белмичәрәк аптырап калды.* Г. Минский.

◇ **Коры калу** — 1) нәрсәдән дә булса мәхрүм калу; югалту. — *Әй, син, аксак, кая чабасың? Әллә икенче аягыңнан да коры калырга йөрисеңме?* Г. Галиев; 2) тимәү, тәтемәү; бернәрсәсез, буш калу. *Һәр кешенең үз нәфсенә көче җитсә, Дәрәҗәдән коры калмас мондый кеше.* М. Гафури. [*Яучы:*] — *Шушы җүләрнең*

тиктормас теле аркасында --- ничә тәңкә сәдака-хәер акчаларыннан коры калдым. Г. Камал. **Коры килү** — ел, бигрәк тә җәй, явымсыз булу, корылык (шуңа бәйле — ачлык) булу турында. *Ел коры килеп, хак шәп булырлык булса, ул боларны [ашлык кибәнен] суктырмаска, алдагы кышка калдырырга исәпли иде.* Г. Ибраһимов. *Җәй, бәхетсезлеккә каршы, коры килде.* И. Гази. **Коры кул белән** — 1) бернәрсәсез, буш кул белән. — *Көн саен [иртә] алып кайтам дип вәгъдә итәм, көн саен коры кул белән.* Г. Әпсәләмов. *Сугышка баргач, коры кул белән бармаганнардыр инде.* М. Гали; 2) максатка ирешмәгән килеш, нәтиҗәсез. *Авылга коры кул белән [әйләнеп] кайтсаң, күзне ачырмаслар.* М. Фәйзи. **Коры кул белән калу** — *к.* коры калу. *Бай акча өчен елый, Чөнки ул акча колы, „Калам бит инде коры Кул белән", — ди бәдәвам.* Г. Камал. **Коры куллы** — таләпчән, эшне үзе дигәнчә һәм тиз тота, ник тора торган. *Әти кеше бигрәк тә коры куллы.* Каз. утл. **Коры куык (кабык)** — мактанчык, шапырынырга, мактанырга ярата торган (кеше). *Сәфәргалинең --- бу коры куык малайның искәртмәстән генә яңагына сугып җибәрәсе килеп бара иде.* Ф. Хөсни. *Боларның [шәкертләрнең] коры кабык икәнлекләрен төшенеп була иде.* М. Гафури. **Коры мунчала белән юу (уу, ышку)** — алдалау; берни дә эшләмичә, сүз белән юмалап кына яшәү турында. *Бар ул шундый мөдирләр — Телгә бик шома алар, Коры мунчала белән Аркаңны юа алар.* З. Мансур. **Коры паек** — ярмалата, онлата яки консерв һ. б. ш. төрле ярым азык хәлендә бирелә торган паек. *Туену пунктының ашханәсенә алып кереп, төшке аш ашаттылар. Шушында ук юлга дип коры паек бирделәр.* М. Әмир. **Коры сөяккә калу** — бик ник ябыгу. *Мин сап-сары, коры сөяк инде... Кроватьта ятам сызланып.* М. Җәлил. **Коры тоту** — 1) таләпчән, каты куллы булу; кызганып тормау, аямау. *Ул башта эшчеләрне коры тотмакчы булды: ник намаз укымыйлар, ник акча уйныйлар, ник эчәләр?* Ш. Камал; 2) тиз бетерү (эшне), тиз эшләү (эшне). *Юбилейга вакыт бик аз калганлыктан, Хәйдәр бөтен яшьләрне аякка бастырып, эшне бик коры тотты.* Г. Бәширов. **Коры хәсрәтләнү** — сәбәпсез һәм нәтиҗәсез кайгыру, юкка, кирәкмәгәнгә борчылу. *Бүген ул әнисенең коры хәсрәтләнеп, юкка кыбырсып йөрүенә бөтенләй үртәлмәде.* Н. Фәттах. **Коры шалтыравык (такылдык)** — *к.* коры куык (кабык). *Давытның бу хыялы ачылачак, Давыт коры шалтыравык булып калачак.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Корыга китү** — яңгыр яумау, явымсызлык башлану, туфракның яңгырга сусавы. *Бер елны шулай җәен һавалар бик корыга китте, бик озак вакытлар бер тамчы да яңгыр төшмәде.* М. Гали. **Корыга (селкенеп) йөрү** — эшсез тик йөрү, максатсыз буш йөреп вакыт уздыру. **Корыга мактану** — нигезсез, урынсыз шапырыну. — *Ташла, дшрәп! Корыга мактанма! Юк бит бернәрсәң дә...* Н. Исәнбәт. **Корыны бушка аудару** — эшсез тик йөрү, берни дә эшләмәү. — *Солтан абзагызның кайчан корыны бушка аударып йөргәне бар?* С. Рафиков.

КОРЫБОТАК *и. әвф.* Чуан, сызлавык. *Чуан дисәң юаная, корыботак дисәң — корый.* Әйтем.

КОРЫК *и.* 1. Чабып барган атны яки башка кыргый хайванны эләктереп аулау өчен бер башына элмәкле бау тагылган озын колга. *[Елкычы] атын әйдәде дә --- сүз әйтеп авыз йомганчы, корык очындагы арканны бер айгырның муенына салды.* Г. Ибраһимов. || Гомумән колга, озын киртә. *[Әхтәри:] У... ходай орган хатыннар! Урядниклар килгәч, таралганнар иде, тагын җыелганнар. Корык белән кудырыйм әле.* Т. Гыйззәт.

2. *иск.* Борынгы сугышларда дошманны ат өстеннән егып әсирлеккә алу өчен кулланылган бер башы элмәкле бау (бауның бер башы ыргытучыда кала, элмәкле башы дошман эләгерлек итеп төзәп ыргытыла һәм, тарткач, элмәк кысыла). *Корал юктан корык та корал.* Мәкаль.

Корык салу (ташлау) — 1) корык белән тоту, аулау; 2) *күч.* бугалак салу; үтерү. *Газраил корык салмаса, әле дә булса, Туктамыш, Синнән калыр картыңмын.* Н. Исәнбәт.

КОРЫК-КОРЫК *аваз ияр.* Ютәлләү тавышын, каты йөткергәндә чыккан тавышны белдерә. | *рәв. мәгъ. Гайнулла карт ике сүзнең берендә корык-корык йөткерә-йөткерә нидер сөйли.* Н. Фәттах.

КОРЫКЧЫ *и.* Корык белән ат тотучы, корык белән мал аулаучы кеше. *Тар җирдә тамаша булма, киң җирдә корыкчы булма.* Мәкаль.

КОРЫЛАЙ *рәв.* 1. Коры (1 мәгъ.) хәлендә, юешләмичә яки юешләнгәнче. *Орлыкларны корылай чәчү.*

2. Коры (8 мәгъ.) килеш, буш, бернәрсәсез (ашауэчү турында). — *Әйдә инде, бу юлы ничек тә корылай гына эчәрсең, — диде вә үзе, тулы гына күкрәген алга чыгарып, аяк очтан гына чәй коярга тотынды.* Ш. Камал.

КОРЫЛАНУ *ф.* 1. Корыга китү; (көннәр) явымсыз, яңгырсызга әйләнү. || Коры хәлгә килү; дымның, юешлекнең кимүе. *Пермь чорында климат корылана төшкән.* Биология.

2. *күч.* Таләпчәнлек күрсәтү, коры тота башлау, каты куллылану. || Коры, салкын, рәсми төс алу; хисләргә ярлылану. *Синең хатларың корыланды, үгетнәсихәткә күчтең, мине читләттең.* А. Гыйләҗев.

КОРЫЛАТА *рәв. к.* корылай 1. *Игенне корылата җыеп алу.*

КОРЫЛДАУ *ф.* 1. Торнаның үзенә хас тавыш белән кычкыруы. *Корылдап кычкырган тавыш.*

2. Этәч яки күркәнең ко-ко-ко кебегрәк кычкырынып куюы. *Юкә белән аягын бәйләп, этәчне арбага китереп салдылар. Этәч, бик аптырагандай, корылдап куйды.* М. Гали.

3. *күч.* Тупас, калын тавыш белән сөйләү (урынсыз һәм ямьсез сөйләвен яратмау төсмере өсти).

КОРЫЛДАШУ *ф.* 1. Торналар кычкыруы, очканда үзара хәбәрләшүе турында. *Торналар корылдаша.*

КОРЫЛМА I *и.* 1. Төзелеш; производство биналары комплексы. *Мәшһүр Братск ГЭСын һичбер икеләнүсез яшьләр төзелеше, комсомол корылмасы дип әйтеп була.* М. Хөсәен. *Ике яктан карт өянкеләр тезелгән, ә алда — учхоз корылмалары.* А. Расих.

2. *хәрби.* Дошманның алга баруын тоткарлау, юлын кисү өчен төзелгән каршылык кыры, киртә. *Безнең батальон танкка каршы корылмалар төзеде.* Ә. Маликов.

КОРЫЛМА II *и. физ.* Предметның электрлануы, анда барлыкка килгән электр; заряд. *Электроскоп — әйбердә электр корылмасы барлыгын белү өчен хезмәт итә.* Физика.

КОРЫЛТАЙ *и. иск.* Аерым губерна, өяз, республика яки дәүләт күләмендә җыелган съезд. *Мөселман комитеты, губернаны төбәкләргә бүлеп, яңадан корылтай чакыруны үзенә алырга уйлый.* Ш. Әхмәдиев.

КОРЫЛУ *ф.* 1. Төзелү, салыну, нинди дә булса корылманың барлыкка килүе. *Шул кара-каршылап, урта өйләп салынган йортның, рус капкалы карт нигезнең ничек корылганын --- үзеннән сөйләтсәң нинди яхшы булыр иде.* А. Шамов. *Далада яңа поселоклар салына, мәктәп, больницалар корыла.* А. Әхмәт. || Ясалу, берәр әйбер яки күренешнең барлыкка килүе. *Киң кунак залы уртасына озын өстәл буйлап бай табын корылган.* Ш. Маннур.

2. Төзелү, булдырылу, барлыкка килү (берәр җәмгыять, коллектив һ. б.). *Менә хәзер шулар кулы белән Социализм иле корыла.* М. Җәлил. *Шулай итеп, контрреволюция аппараты корыла.* Ш. Камал.

3. Оештырылу, комбинацияләнү; ижат ителү. *Гарәпчә, фарсыча, азербайҗанча, тагын әллә нәрсәчә телләрдән корылган шигырьләр дә күптер.* Ф. Әмирхан. *Нәфисә үзе тирәсендә яшерен тозаклар корылуын сизә.* Г. Бәширов.

4. Төзәтеп, эшкә, хәрәкәткә әзер хәлгә китерелү (машиналар турында). *Иген коралларыгыз корылмаган.* Т. Гыйззәт. *Кичтән ай яктысы белән машина корылып беткән иде.* Г. Ибраһимов.

5. Элену, элеп, нинди дә булса урын каплатып куелу (пәрдә, чаршау турында). *Уң яктагы ишекне чыккач, чаршау корылган.* Ф. Бурнаш. *Фәрит кунакларны маскировкасы корылган килеш калган мунчага алып керде.* Г. Гобәй.

6. Нигезләнү, исәп тотылу. *Ул семья тормышы белән артык кызыксынмый, аның төп идеалы мал җыюга, сату итүгә корылган.* М. Гали.

КОРЫЛУЛЫ *с. сөйл. к.* корулы 1. *Газизә, корылулы урынның бәр кырыена утырып, өстәл янындагыларны бер читтән карап тора иде.* Ш. Камал.

КОРЫЛЫК *и.* 1. Коры булу хәле; юешләнмәгән, чыланмаган, дымланмаган булу. *Аучылар башлыгы Хуҗа өстендәге киемнәрнең корылыгын күреп: „Хуҗа, нигә синең өстең коп-коры?“ — дигән.* Мәзәк. *Дымлы, юеш землянкадан соң мондагы корылык, яктылык аларга бик зур рәхәтлек булып, җәннәт булып тоелды.* Г. Ахунов.

2. Озак вакытлар яңгыр булмау, явымсызлык сәбәпле, җир һәм һавада дым бетү, үсемлекләр кору, һәлак булу. *Корылык зарар китермәсен Коллектив хуҗалыкка.* Ә. Ерикәй. *Дәһшәтле дошман — корылык Мәңгегә беткән булыр, Бар җирдә байлык һәм муллык Тулып һәм ташып торыр.* Ә. Исхак.

3. *күч.* Коры (10 мәгъ.) булу, таләпчәнлек; катылыкүңеллелек. *Гаязның бу корылыгы Зояны тагын ныграк каушатты.* М. Әмир. — *Анысы безнең эш түгел, — диде Дәүли, кискен корылык белән.* Э. Касыймов. || Салкынлык, хиссезлек, рәсмилек. *„Кашларын бераз каралта икән бу туташ“ дигән фикер әллә нинди шигъриятсез корылык белән Шакирның башына килде.* Ф. Әмирхан.

КОРЫЛЫКЛЫ *с.* Коры, дымсыз; явымсыз (һава торышы турында). *Корылыклы районнар.* □ *Корылыклы һава вакытында* [яшелчәләр төбен] *йомшартуны 2—3 см тирәнлектә генә үткәрәләр.* Җиләкжимеш...

КОРЫЛЫШ *и.* 1. *к.* төзелеш. *Яңа корылышлар мәйданы.*

2. Төзелеш, композиция, структура (әдәби һәм музыка әсәрләре турында). *Язучылар* [әсәрләрен] *музыканың характерына һәм корылышына яраштыру техникасын үзләштерделәр.* М. Җәлил.

КОРЫЛЫШЛЫ *с.* Төзелешле, төзелгән, корылган. *Габдулланың алды әллә нинди аңлаешсыз гажәп корылышлы тартмалар, серле котыйчыклар белән тулды.* Ә. Фәйзи.

КОРЫМ *и.* Ягулык янганда барлыкка килә торган кара төстәге майлы продукт, ягулык калдыгы (төтен белән һавага күтәрелеп, җир өстенә ява, әйберләргә куна). *Җимерелгән шәһәр яна дөрләп, Кайный төтен, корым коела.* Ф. Кәрим. *Нәгыймә мичтән бармагына корым сылап килде.* М. Гали. || *типогр.* Типографиядә куллану өчен махсус эшләнгән кара буяу. *Полиграфия промышленносте һәм газ промышленносте институтлары сотрудниклары китап басу өчен махсус корым эшләп чыгардылар.* Соц. Тат.

КОРЫМБАШ *и. а.-х.* Үсемлекләрдә, аеруча бөртекле ашлыкларда була торган гөмбә авыруы; кисәү гөмбәсе.

КОРЫМЛАНУ *ф.* 1. Корымга, төтенгә каралу, буялу. *Галәү бабай шырпы сызды да корымланып беткән унлы лампаны кабызды һәм, авыз эченнән нидер сөйләнә-сөйләнә, ишеккә килде.* Г. Гобәй. *Тагы азрак баргач, завод-фабрика биналарының корымланган кара гәүдәләре күренде.* М. Гафури.

2. *к.* корымлау. *Лампа корымланып яна, бераз басарга кирәк.*

КОРЫМЛАУ *ф.* Корым, төтен чыгару, төтәү. *Керосины начар ахры, лампа корымлый.*

КОРЫМЛЫ *с.* 1. Корымга, төтенгә буялган, каралган. *Бер якка кыйшайган мичнең корымлы авызы шомлы гына ыржаеп тора.* А. Шамов. *Якын-тирә урамнар, чатлар — һәммәсе әле күбе эш киемендә булган корымлы өс-башлы эшчеләр белән капланып беткән иде инде.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Пычрак, кешене каралта, буйый торган, намусын таплый торган (сүз, гайбәт һ. б.). *Әнә, кайсыдыр адәм актыгы тараткан бик әшәке сүзләр. Ана күңеле сизенми калмас, ул корымлы сүзләр, ихтимал, әсгатькә дә килеп ирешкәндер.* Р. Төхфәтуллин.

КОРЫ-САРЫ *и.* 1. Корыган ботак, йомычка, чыбык-чабык кебек вак-төяк утын, ягулык. *Ботаклардан коры-сары сындыргалап самоварга салдылар һәм аны шаулатып җибәрделәр.* Ә. Фәйзи.

2. Сыек булмаган ашамлыклар. *Ял көннәрендә төрле коры-сары пешерттереп --- Арча кырына менелә.* Ә. Исхак. *Хәзәр кичләрен коры-сары кимереп утырмыйбыз.* М. Галәү.

КОРЫТУ *ф.* 1. Сөртеп коры итү, киптерү. *Үзенә тигән сыерларның имчәкләрен җылы су белән юып, ап-ак чүпрәк белән корыта, аннан соң аз гына майлап ала да сава башлый.* Ә. Айдар.

2. Үсемлекләрне корыган хәлгә китерү, үсүдән туктату, һәлак итү. *Дуңгыз гөл бакчасына* [эшкә] *ялланган, ләкин ул анда, гөлләрне карау урынына, тик аларның тамырларын казып, корытып кына йөри.* Г. Тукай. || Җан иясен, аның органын яшәүдән туктату, һәлак итү. *Җырлый-җырлый үлгән безнең Тукай, Үпкәләрен микроб кортса да...* Ш. Маннур.

3. *күч.* Бөлдерү, талап-жимереп хәерчеләндерү, бөлгенлеккә төшерү. — *Нинди күңелле булыр иде шушы каһәр төшәсе нәрсәләр ил корытып йөрмәсәләр, — дип, Гафият уйланып кайта.* И. Гази. || Бөтенләйгә юк итү, бетерү, туздыру. *Әгәр авыл советы кирәк таба икән, без үзебез, дружина төзеп, ак бандитларны туздырырга, тамырларын корытырга керешер*[*без*]. Ш. Камал. *Бөтен халык кырга чыга Корылыкны корытырга.* Ә. Ерикәй.

КОРЫЧ *и.* 1. Тимер белән углерод һәм кайбер башка төр катнашмалар эретмәсеннән торган аксыл каты металл. *Мин балтаны корычтан эшләтәм.* Г. Ибраһимов. *Миллион, йөз миллионнарча корычы бар безнең дәүләтнең.* Р. Ишморат. || *с. мәгъ.* Корычтан эшләнгән. — *Корыч танкларга утырырбыз да нахакка аккан совет кешеләренең каннарын даулырбыз.* Т. Гыйззәт.

2. *с. мәгъ. күч.* Көчле, җиңелмәс. *Калды сыйныф, Калды корыч армия, Ленин юлын үтәүче, Социализм төзүче, Калды Ленин — партия!* Ф. Бурнаш. *Фронтларга көчле, җимерелмәслек Корыч колонналар бирербез.* Һ. Такташ. || Нык, ныклы; какшамас. *Корыч ихтыяр.* □ *Корыч дисциплина булачак аның фермасында.* Ә. Еники. *Ярый әле, сәю белән бергә Бар йөрәктә корыч түземлек.* М. Җәлил.

Корыч юл — *иск. к.* тимер юл. *Җир астыннан үткән корыч юллар, Күктә янган рубин йолдызлар Дәрт тудыра безнең йөрәкләрдә Һәм тудыра яңа шат җырлар.* Ә. Ерикәй.

◇ **Корыч ат (айгыр, аргамак, юртак...)** — трактор. *„Әй, Тимергали, күрәсеңме, умыра бит бу корыч аргамаклар!" --- Унбиш кешенең корыч атларга атланып сукалаган җирләре --- бик күп агайларның уйларын чуалтты.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Корыч йөрәкле** — батыр, кыю, курку белми торган. *Кемнәрдер бәйрәмнәрдә безнең корыч йөрәкле дустыбыз каберенә, немецларга күрсәтми генә, чәчәкләр дә сала башлаганнар.* А. Шамов. **Корыч кош (лачын)** — самолет. *Корыч кошка утырып шунда Өч кыз бергә ерак юлга чыгып киткәннәр.* Ә. Исхак. *„Юк, булмас ул!" — диде Исмәгыйль һәм, кызулап корыч лачынын, Куып җитте фашист актыгын.* Ш. Маннур.

КОРЫЧАГАЧ *и.* Зәйтүн агачы семьялыгыннан көньякта үсә торган, тар, вак яфраклы, үзәге бик каты агач; дардар агачы. *СССР Европа өлешенең көньягында урман полосалары булдыру өчен имән, корычагач, нарат, акация, тополь --- утырталар.* Биология.

КОРЫЧЛАНУ *ф.* 1. Корыч хәленә килү; корыч броня белән каплану. *Кояш киң күңелле, җир кешесен Үз постына тигез урнаштырган: Миңа корычланган каләм биреп, дхмәтшага комган тоттырган.* М. Җәлил.

2. *күч.* Ныгу, чыныгу. *Корычланып, кырысланып беттем, Еллар мине шулай иттеләр.* Х. Туфан. *Әйтерсең, җәһәннәм утларында кайналып корычланып чыккан бер егет — менә шулай күренде миңа Шаһбаз дустым.* Г. Ибраһимов.

КОРЫЧЛЫК *и.* Корыч кебек нык булу. *Кирәк аңа бөтен җирнең Тынычлыгы, Тынычлыкның какшамаслык корычлыгы.* Г. Латыйп.

КОРЫЧЧЫ *и.* Корыч коючы, корыч кою остасы. *— Атаклы корыччы иптәш Тимергалиевне --- социалистик ярышка чакырам.* Н. Исәнбәт.

КОРЫШКАК *с. сөйл.* Чирләшкә, ябык, арык тәнле (балалар турында). *Биграк корышкак бала инде.*

КОРЫШТЫРУ *ф.* 1. Вак-төяк, юк-бар нәрсәләрдән, аннан-моннан гына төзү, эмәлләп кую. *Яңа такталардан корыштырган зур гына каралты сыман кәмитнең нигезеннән алып түбәсенә кадәр күз камаштыргыч буяулы сурәтләр.* Ә. Фәйзи. *Мунчасын корыштырып бирдек, хәтта мичен дә чыгардык.* А. Шамов. || Төрле кисәкләрне җыйнап бер бөтен итү, бер бөтен итеп күз алдына китерү. *Сүрә һәм аятьләрдән корыштыра торгач, алла безнең алга нәкъ безнең кебек кеше булып килеп баса.* Г. Гобәй.

2. Җыйнау, җыйнакландыру. [*Муса*] *бөкрәйгән гәүдәсен тагын да корыштыра төште һәм, сикереп киткән резин туп җиңеллеге белән, артиллеристлар янына йөгерде.* Ш. Маннур.

КОРЫШУ *ф.* 1. Тулылыгы бетеп җыерылу, сулу, шиңү (үсемлек турында). *Чәчәк тә бит Карлы җилдән шиңеп корыша.* М. Җәлил. || Кору, кибүдән җыерылу, бөтәрләнү, йомарлану. *Тирене корышып кипмәсен өчен тарттырып куялар.*

2. Картлык яки авырудан үтә ябыгу, бетеренү, тәннең тулылыгы, турылыгы югалу (кеше яки хайван турында). *Бичара Арслан корышкан, салынган аяклары өстендә үз гәүдәсен көчкә генә күтәреп йөри башлады.* Г. Тукай. — [*Юныс Вәлишин*] *каныгызны шундый итеп суырыр... Җелекләрегез кибеп корышканчы.* К. Нәҗми. || *күч.* Кечерәеп, мескенләнеп калу. *Хуҗасыз йорт кына Корышып утыра җиргә кар яткач.* С. Сөләйманова.

3. Аяк яки кулның авыру нәтиҗәсендә коруы, тартышуы, эшкә ярамавы. *Җәмиләттәй корышкан куллары белән битен сыйпап алды.* Н. Фәттах. — *Кәһәр сукысын инде, моны язган кешенең кулы корышса иде, ходаем.* Ш. Мөхәммәдев. || Гомумән гәүдәнең тартылуы, җыерылуы. [*Мусаның*] *үз йөрәгенә дә курку керә... бөтен гәүдәсе корыша башлый, учка кысылган кар шикелле йомарлана.* Ш. Маннур.

КОРЯК *и.* Камчатканың Коряк милли округында яши торган төп халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. || *с. мәгъ.* Коряк халкына караган, шул халыкка бәйләнешле. *Коряк теле.*

КОСЕ'КАНС *и. мат.* Тригонометрик функцияләрнең берсе — өстәмә почмак секансы.

КОСИ'ЛКА *и. сөйл.* Печән чабу машинасы. *Косилкалар белән Быел печән чаптык болында.* Ә. Ерикәй. *Косилканың тәртәсе дуга белән күтәрелеп куелган, аңа камытлар, дилбегәләр әлегән.* М. Фәйзи.

КО'СИНУС *и. мат.* Тригонометрик функцияләрнең берсе — өстәмә почмак синусы. *Класс, ишетелеришетелмәс кенә каләм шыгырдатып,--- косинус белән синус, икс белән игрек эзли.* Р. Төхфәтуллин.

КОСМЕ'ТИК I *с.* Косметикага караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Косметик чаралар куллану.*

КОСМЕ'ТИК II *и.* Косметика врачы. || Косметика әйберләре белән сату итүче.

КОСМЕ'ТИКА *и.* 1. Гигиена һәм нәфислек өчен тәнне, бит һәм чәчне карау, тәрбияләү чаралары. *— Дөрес булса, сез Парижга барып косметика курсларын да бетереп кайткансыз.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. Бизәнү, биткә, тәнгә ясалма матурлык, нәфислек бирү әйберләре. *Косметика кибете.* □ *— Галантерея, косметика товарларына скидка ясату комиссиясе кирәк.* Ә. Фәйзи.

КОСМЕТО'ЛОГ *и.* Косметика белгече. *Косметологлар да алоэ согы һәм эмульсиясе белән кызыксыналар.* Азат Хатын.

КОСМЕ'Я *и. бот.* Катмарлы чәчәк ата торган берьеллык үсемлек, бакча гөле.

КО'СМИК *с.* 1. Космоска бәйләнешле; космос, галәм күләмендәге. *Космик очышлар.* || Космоска оча торган. *Космик ракеталар.* □ *Әнә Харисның әнесенә космик корабльләр төзермен.* Ә. Бикчәнтәева.

2. Гаять зур, грандиоз, гигант. *Космик адымнар белән алга бару (үсеш).* □ *Бибиҗамал апаның вәсвәсә гидрасы космик тизлек белән үсте.* Ш. Хөсәенов.

Космик биология — тереклек ияләренә космостагы шартларның ничек тәэсир итүен, көсмоста терек организмның (бигрәк тә кешенең) яшәешен, үзгәрешен тикшерә торган фән. **Космик нурлар** — галәм киңлегендәге, кояштан башка йолдызлардан тарала һәм Җир атмосферасының югары катлавына үтеп керә торган зур энергияле нурлар. **Космик тизлек** — планеталар яки йолдызлар арасындагы бушлыкта була торган каты вак кисәкчәләр — тузан бөртекләре.

КОСМОВИ'ДЕНИЕ *и.* Космостагы әйберләрнең, күренешләрнең сурәтен, рәсемнәрен кабул итү. *Безнең илне космовидение ватанына әверелдергән тапшырулар — космостан тапшырулар совет телевидениесенең чын тантанасы булып тора.* Соц. Тат.

КОСМОГО'НИЯ *и.* Астрономиядә күк җисемнәренең килеп чыгышы һәм үсеше турындагы мәсьәлә белән шөгыльләнә торган бүлек.

КОСМОГРА'ФИЯ *и. иск. к.* космология. — *Их син, юлар, дәү әни кеше монда имтихан тотып чыкты; ә син аякларым дип ятасың, төкер аякларыңа, --- латин белән космографиядән* [*икеле*] *алма.* Ф. Әмирхан.

КОСМОДРОМ *и.* Космик корабльләрне җибәрү өчен махсус җиһазланган мәйдан. *Һәркем космонавт була алмый, кемгәдер космодром төзергә дә кирәк,— дидә* [*Варис*]. М. Хәсәнов.

КОСМОЛО'ГИЯ *и.* Астрономиядә космос, галәм төзелеше, аның гомуми үзенчәлекләре һәм үсеше турындагы бүлек.

КОСМОНА'ВТ *и.* Космоска, галәмгә очучы. *— Уңберенче космонавт мин булырга тиеш, — ди* [*Җәмил*]. Б. Камалов. *Кем белә, бәлки* [*В. Терешкова*] *үзенең сеңелләрен, булачак космонавт кызларны тагын да ераграк, тагын да кыюрак сәяхәтләргә әзерлидер.* Л. Ихсанова.

КОСМОНА'ВТИКА *и.* Космоска, галәмгә очучылык. *Доктор космонавтиканың нигезләрен өйрәнде.* А. Тимергалин.

КОСМОНАВТЛЫК *и.* Космонавт булу. *Космонавтлыкка кандидатларны сайлап алу турында авиация баш маршалының приказы бар.* К. Латыйп. *Хәтерең дәдәр, космонавтлыкка алуларын сорап без бер хат язган идек.* Ф. Яруллин.

КОСМОПЛАН, КОСМОЛЁТ *и.* Космоска очу өчен җайланган һава корабле. *Космоплан кайтыр юлының күп өлешен автомат рәвештә очканга күрә, сәяхәтчеләргә үз эшләре белән шөгыльләнергә мөмкин булды.* А. Тимергалин.

КОСМОПОЛИТ *и.* Үз милләтенә, үз иленә карата патриотик хисе булмаган, үз ватанына, милли культурасына түбәнсетеп карап, космополитизм идеяләре белән сугарылган кеше. *Ул кеше индә үзенең нинди милләттән икәнен дә онытмкан, ул милләтсез, ягъни мәсәлән, космополит.* И. Гази. *Мин хәзерге заман героен җирсез һәм илсез... ниндидер нигилист-космополит итеп күрсәтү белән һич килешә алмыйм.* Г. Бәширов.

КОСМОПОЛИТИЗМ *и.* Үз иленә, үз халкына, милли культурага илтифатсыз караш яклы реакцион буржуаз теория; бу теория халыкларның милли бәйсезлеге өчен көрәшенә каршы чыгып, „бөтендөнья дәүләте“ төзүне — империализм политикасын алга сөрә, патриотизм һәм пролетар интернационализмны инкяр итә.

КОСМОПОЛИ'ТИК *с.* Космополитизмга мөнәсәбәтле. *Космополитик әдәбият. Космополитик карашлар.* □ *— Тукайның милләтчелек белән көрәше һич тә ниндидер бер космополитик позициядән - - - алып барылмады.* Г. Халит.

КОСМОПОЛИТЛЫК *и. к.* космополитизм. *Күпләре институтларда өйрәнгән чит ил телләрен дә онытып бетергәннәр икән... „Космополитлыкта гаепләрләр дип куркалардыр“, — диде Макаров көлеп.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Космополитизмга караган (кагылышлы), шуңа бәйләнешле; космополит булу. *Космополитлык идеяләре.*

КО!СМОС *и.* Барлык форма материяләрнең бер бөтен җыелмасы, барлык планеталар, йолдыз һәм йолдызлыклар бергә; галәм. *Равил бик зур тырышлык белән космоста очып бара торган ракета рәсеме ясап утыра иде.* А. Расих. *— Мин космоска очарга җыенмыйм әле, шушы колхозда тормыш итәргә исәп.* М. Шабай.

КОСТЁЛ *и.* Поляклларда католиклар чиркәве. *Олырак яшьтәгеләре поляк костелларына карап теләр-телəмәс кенә чукына.* Ф. Хөсни. [*Познаньда*] *әллә нихәтле бик борынгы биналар, мәһабәт костеллар, иске ныгытмалар калкып кала.* Ш. Маннур.

КОСТЁР *и. к.* учак 2. [*Пионерлар*] *кабер өстенә чәчәкләр утырталар, җиде баһадир хөрмәтенә костёр яндыралар, баһадирларга атап чыгарылган шигырьләрен укыйлар.* Г. Гобәй. *Минем дуслар — костёр ягучылар Бик күңелле итеп ял итә.* С. Хәким.

КОСТЫЛЬ *и.* 1. *сөйл.* Култык таягы. [*Яралылар*], *костыльләренә таяна-таяна, докторлар белән янәшә сафка тезелә башладылар.* Н. Дәүли.

2. *махс.* Рельсны шпалларга беркетү өчен эшләнгән махсус кадак. *Ачкычлар, ломнар эшкә тотындылар... Шөреплəр, костыльләр урыннарыннан кузгалдылар, рельслар үзләренең башларын бордылар.* Г. Гали.

КОСТЫРГЫЧ *с.* Костыра торган, ашаганны кире чыгара торган. *Костыргыч дару эчү.*

КОСТЫРУ *ф.* 1. Косарга, ашаган-эчкәнне кире чыгарырга мәҗбүр итү. *— Беркайчан да урта гасыр врачларына охшарга тырышмагыз: костыра торган дарулар кулланмагыз, кан алу белән мавыкмагыз,— дидә ул.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Ашаганы кире килерлек итеп үч алу, үзләштергән әйберләрен көч белән тартып алу турында. *Бик күп илләрне, бирән корсак, кабып йоткан идең, Костырырбыз йоткаңыны, тотса Мәскәүләр якаң!* Ә. Исхак. *Тиздән без аларны корыч йөгәнгә алырбыз да хәзер арттырганын* [*җыйганын*] *да костырырбыз.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КОСТЮМ *и.* 1. Чалбар-пиджактан, кайчак жилеттан да торган ирләр киеме. *Матуррак костюм, чибәррәк кепка киеп йөргәндә, нәрсә югалтасың инде?* Ш. Камал. *Ул үзенең коңгырт озын чәчен артка җибәргән, ак якадан, галстуктан, яхшы костюмнан.* М. Гали. || *сөйл.* Костюмның бер өлеше — пиджагы. *— Тикшерү күрсәтер, — диде дә, өстендәге шакмаклы костюмының төймәләрен бер ычкындырып, бер төймәләп озак кына иснәп алды.* К. Нәҗми.

2. Жакет белән юбкадан (яки сарафаннан) торган хатын-кыз күлмәге, костюм-күлмәк. *Өстенә күгелҗем төсле кара костюм, башына киң читле кара эшләпә кигән кара туткыл йөзле, озын буйлы бер туташ каядыр бик ашыккан кеше кебек җилләнеп килеп чыкты.* Г. Ибраһимов. || Ирләр костюмына (пиджагына) охшатып тегелгән хатын-кыз пиджагы. *Шакмаклы костюм кигән хатын, киосктан ераклашып, халык арасына кереп бара иде.* А. Шамов.

3. Аерым очрак яки эш өчен тегелгән киемнәр комплексы. *Пляж костюмы. Эш костюмы. Спорт костюмы.* □ *Чаңгы костюмы килешә үзенә* [*Гөлнурга*], *зәңгәр башлыгы белән бик пар килеп, ятышып тора.* Г. Ахунов. || *театр.* Нинди дә булса образны гәүдәләндерү өчен кирәк булган сәхнә киеме. *Театрга күп кенә ярдәмче цехларны оештырырга - - - кирәк булды. Болар эченә тегү, монтировка, декорация, костюмнар, парикмахерлык һ. б. цехлар керәләр.* М. Җәлил. *Район күчмә театрыннан бүре һәм шүрәле костюмнары сорап алып кайттылар.* Г. Гобәй.

КОСТЮМЕР, КОСТЮМЕ'РША *и.* Театрда костюмнарга җаваплы кеше. *Костюмер булып эшләү.* □ *Артистлардан башка тагын костюмершалар, сәхнә эшчеләре - - - барлыгы 45 кеше җыелып местком сайладык.* Каз. утл.

КОСТЮМЕ'РНЫЙ *и.* Театрда костюмнар саклау бүлмәсе.

КОСТЮМЛЫК *с.* Костюм тегү өчен эшләнгән. *Костюмлык трико.* || Костюм тегәргә җитәрлек. *Сафый абзыйны костюмлык йон тукыма белән бүләкләделәр.* Азат хатын.

КОСУ *ф.* 1. Ашаганны кире чыгару; ашказанындагы азык калдыкларын авыздан ихтыярсыз кире чыгару. *Безнең шәһәр байлары Мәскәү малын сосалар, Корзинкалап сыра эчкәч, чыдый алмый косалар.* Ш. Мөхәммәдев. *Кайбер иптәшләребездә инде диңгез*

авыруы башланды: алар укшыйлар, косалар иде. Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Берәр кешенең үз-үзен тотышына карата туган килештермәү, җирәнү хисе турында. — *Косарсың килешләренә! Кеше ашаган аш ярамый, кеше кигән кием ярамый.* Г. Камал.

3. *күч.* Җиңелеп, башкалардан алган, талап җыйган нәрсәләрне кире кайтарырга мәҗбүр булу турында.

4. *күч.* Күпләп чыгарып тору турында. *Ялт-йолт итеп балкып күренәләр Чуен коса торган домналар.* М. Гафури.

5. *сөйл.* Тимергә тиеп торган нәрсәгә тимер тутыгы чыгу, шул әйберне каралту. *Борчак ашын ул чуенда пешерә күрмә, коса. Бу чилэк коса, җиләкләреңне тизрәк бушат.* Сөйләм.

КОСУР *и. иск. кит.* Кимчелек, җитешсез як. *Алам-салам ак якалар куелмаса, Була инде гүяки бер косур кебек.* М. Гафури. *Безем яздыкларымызда да косур һәм дә бөек косурлар* [*булыр*]. Г. Тукай.

КОСЫК *и.* Косып чыгарылган нәрсә. *Ватылган савыт, ташланган азык, ауган урындык, җимерелгән өстәл, пычранган әйберләр арасында кешеләр косык эчендә ауный, кайсы укшый.* Ш. Камал.

Косык даруы — *к.* костыргыч. *Бүлмәнең бер почмагында берәү косык даруы эчеп косып ята.* М. Гафури.

КОСЫ!НКА *и.* Өчпочмаклы яулык; кыек яулык, кыекча. [*Марина*] *чуар косынка бәйләгән, Күзләр — җитен чәчәге.* С. Хәким.

КОСЯК *и. махс.* Уылдык чәчү чорында бер урынга җыйналган балык өере. *Кешеләр, балык косягы шикелле ышкылып, сугылып, һаман бер тирәдә уралалар.* Ә. Еники.

КОТ *и. иск.* **1.** *дини.* Тәннән аерылып китә ала дип уйланылган җан; рух. *Бишенче көнне аның күзгә күренмәс күбәләк булып янында гына очып йөргән коты кире авызына керде. Үлем белән яшәү арасында тартыш төкәнде.* Н. Фәттах. *Ишектән дә кер, котым, тишектән дә кер, котым, үрдәк күк бакылдап кер, каз кебек какылдап кер...* (куркулык койганда әйтелә торган сүзләр). || Шайтан кагылмасын, зәхмәт тимәсен дип яки башка максат белән янда йөртү өчен койдырып эшләнгән „җан“, „кот“ сурәте. *Галимә апаны --- төрлечә им-том иттерә башладылар. Күрше карчыгыннан кот койдыру, Җәлә суфыйдан өшкерту --- кебек эшләрнең берсе дә калмады.* М. Гафури.

2. Нур, ямь; матурлык. *Өйләрдә кот калмады, туган җирдә ямь калмады.* Н. Фәттах. *Баласыз өйдә кот юк.* Әйтем.

3. Бәхет, уңыш. *Кансызга кот кунмас, умартасында корт тормас.* Мәкаль. || Файда, бәхет китерү турында. *Яхшы туса, илгә кот, яңгыр яуса, җиргә кот.* Мәкаль.

Кот(ын) алу (очыру) — бик нык куркыту. *Гүя өйдә һәркемнең котын очырып, җанын бармак очына төшергән, катылыгы, суыклыгы белән йөрәкне туңдырган бер явыз куәт, бер кара көч хөкем сөрә иде.* Г. Ибраһимов. **Кот алыну, кот очу (чыгу), кот калмау** — бик нык курку, шүрләү. — *Урам уртасына чыгып, бер револьвер шартлатсаң, котлары алына бит аларның.* Ш. Камал. — *Һич җил-яңгыр тидерми иркәләп үстердвгез дә, инде үзегезне гомерлеккә оятка калдырганында да бер сүз әйтергә котыгыз чыгып тора.* М. Фәйзи. *Менә килеп безне дә үтерәләр дип котыбыз калмады.* Г. Коләхметов. **Кот ботка җитү (бугазга килү, табанга яки тубыкка төшү)** — *к.* кот алыну. *Котым бугазыма килде, кырыкмаса кырык хуҗа, белеп тә бетермәссең.* А. Алиш. *Залдагылар һаман үкерәләр, йодрык кизәнәләр. Бирде, без әйтәбез, жарны! Котларын төшерде тубыкларына!* К. Нәҗми. *Бәхеткә каршы, көндезге тәрбияче әнине белә икән, яшь чагында дус булганнар, шул җайлады. Котым ботыма җиткән иде югыйсә.* А. Гыйләҗев. **Кот очарлык (чыгарлык)** — *к.* коточкыч. *Шундый ачулы, шундый кайгылы, күрсән, котың очарлык.* Т. Гыйззәт.

КОТАНАЙ *и.* Кот кою, күрәзәлек итү, сихер-багу кебек эшләр белән шөгыльләнүче карчык. || Убырлы карчык. *Бытбылдык кебек симез кызлар, котанай кебек арык кызлар, һәммәсенә дә өстән карый торган „карт кыз“ Җәмилә дә* [*залга*] *--- чыкты.* Г. Газиз.

КОТА!НГЕНС *и. мат.* Тригонометрик функцияләрнең берсе — өстәмә почмак тангенсы.

КОТАЮ *ф. сөйл.* **1.** Кот, җан керү; тазарып, матураеп, тулыланып китү (мәсәлән, авырудан соң). *Кыямәтсез җан булмас, Котаймас тән булмас.* Мәкаль.

2. Тиенү, нәрсәнең дә булса җитәрлек булуы турында. *Тимерче пычакка котаймас.* Мәкаль. *Угры малга котаймас.* Мәкаль.

КОТЕЛОК и. **1.** Гаскәриләр үзләре белән йөртә торган тоткалы кечкенә металл савыт, аш савыты (утка асып аш пешерергә дә ярый). *Бары котелок белән иртәнге аш алып кайтучы солдатлар гына очраштырып куя, аларның котелокларыннан чыккан аш парларын җил уйнатып очыра.* Г. Гобәй. *Котелогында чәй кайнап чыкканда, ул җылынырга һәм бераз хәл җыярга өлгергән иде инде.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Котелок рәвешендә эшләнгән түгәрәк өсле, тар читле каты эшләпә. *Хөсәен өстенә шәп трико костюм, башына котелок кигән, муенга модный бант бәйләп җибәргән.* А. Расих.

КОТЕ!ЛЬНЫЙ *и.* Пар казаннары куелган бина, бүлмә. [*Мусалар*] *завод моржасыдай биек күренгән котельный моржалары арасына барып керделәр.* Ш. Маннур.

КО!ТИК *и.* Тын океанның төньяк өлешендә яшәүче, затлы мех бирә торган диңгез җәнлеге; диңгез мәчесе. || Шул хайван тиресеннән эшләнгән мех. *Котик бүрек.*

КОТИРО!ВКА *и. фин.* Чит ил валюталарына, кыйммәтле (процентлы) кәгазьләргә, товарларга биржа бәясе кую, бәяләү эше. *Котировка комиссиясе.*

КОТКАРУ *ф.* **1.** Бәла, һәлакәт, үлем һ. б. дан саклап калу, йолып калу. *Бу авырлыктан сине кемнәр йолар, кем коткарыр?* М. Гафури. *Сез дә бит геологны коткармакчы булгансыз.* А. Әхмәт.

2. Азат итү, кемнең дә булса кулыннан, изү-кысуыннан тартып алу. — *Безне дошман коллыгында калдырмагыз, коткарыгыз! — диләр.* Г. Бәширов. *Без үзебезне генә түгел, күпме илләрне коткардык.* Ә. Еники. || Азатлык, ирек бирү. — *Коткарыгыз безнең ирләребезне! Алла хакы өчен безне тол, ятим калдырмагыз!* М. Гали. *Сигез негр көрәшчесен коткаруны бүген даулыйбыз.* Ф. Кәрим.

3. Әләккән, кысылган урыннан тартып алу, ычкындыру. *Нәфисә, кызарынып, ачуланып, юбка итәген Миңсылу кодача кулыннан коткарырга кереште.* Ф. Әмирхан.

КОТ-КОН *җыйл. и.* Төс, чырай. — *Бик курыктым, бер дә котым-коным калмады, бөтенләй, бер дә хәлем юк, аякларымның тәмам җегәрлеге бетте.* Г. Камал.

КОТКУ *ф. диал.* Коткы тарату, котырту. — *Халыкның артында мулла белән кулак коткы тормаса, халык ул синең динеңә бик ул хәтле кайнар да карамый.* Ш. Камал.

КОТКЫ *и.* **1.** Коллективта, кешеләр арасында таркалыш кертү, бер-берсенә каршы кую, берәр төрле

җинаятькә этәрү максаты белән сөйләнгән сүз, гайбәт, яла. *Халыкның артта калган күпчелек өлеше, байлар, куштаннар һәм муллалар коткысына бирелеп, яшьләрне хөкем итә.* М. Җәлил.

2. Вәсвәсә; берәр нәрсәгә кызыктырып алдау. *Яшьлекләре белән төрле коткыга ияреп киткәннәр икән, куып чыгару юлы белән түгел, бәлки үз яныбызда калдыру юлы белән аларны һәлакәттән коткарабыз.* Ә. Фәйзи. — *Яшьлек — юләрлек дигәндәй, сез минем улымның качыннар коткысы белән китүен беләсез.* Ф. Бурнаш. || Сиздерми генә яман эшкә өндәү, вәсвәсәле киңәш. *Бердәнбер балам дип анасы аны иркәли, „Шулай бул да болай бул“ дип Коткыны һәм биргәли.* Ш. Мөхәммәдев.

◇ **Коткы салу** — вәсвәсә кертү, күңелен аздыру. [*Мулла:*] *Сезне диннән яздыралар, төрле коткы салалар; Колхозларга куып кертеп, малыгызны алалар.* М. Җәлил. **Коткы тарату** — провокация белән шөгыльләнү, таркалыш кертергә маташу; паника, шик кузгату. — *Кем өйрәтте коткы таратырга, фетнә борчасы!* К. Нәҗми. **Коткы таратучы** — *к.* коткычы. *Кычкыра да коткы таратучы, Җыеннан ук чыгып ычкына.* Ш. Маннур.

КОТКЫЛЫ *с.* Коткыга нигезләнгән, таркалыш ясау максаты белән эшләнгән, провокацион. *„Әллә нинди отрядлар“ турында кулаклар тарафыннан таратыла торган коткылы гайбәтләргә урын калдырмаска кирәк.* Ш. Камал.

КОТКЫНАМӘ *и. иск.* Берәр эшкә, хәрәкәткә өндәп, коткы сүзләре язылган кәгазь. [*Башкин*] *бер кәгазь алып Зәйнетдин муллага сузды: — Менә мондый коткынамәне күргәнегез бармы?* Г. Минский.

КОТКЫЧЫ *и.* Коткы таратучы, провокация белән шөгыльләнүче. *Монда юк-бар коткычылар керә. Шуңа күрә каравыл куйдык.* Г. Ибраһимов.

КОТКЫЧЫЛЫК *и.* Коткы салу, котырту, коткы тарату эше. *Коткычылык белән шөгыльләнү.*

КОТЛАУ ф. **1.** Бәйрәм, юбилей, җиңү һ. б. шатлыклар уңае белән яхшы, изге теләкләр теләп тәбрикләү. — *Сине Совет Армиясенең 25 еллыгы белән котлыйм һәм дошманны җиңеп, исән-сау кайтуыңны чын күңелдән теләп калам.* Г. Гобәй. *Кешеләр бәрсен-берсе котлый азатлык белән.* М. Гафури. | *с. мәгъ. Котлау телеграммасы.* □ *Немец, инглиз, француз, япон, рус һәм татар телләрендә сөйләгән бик күп котлау сүзләреннән соң съезд эшкә керешә.* М. Гали. || Яңа кием, өй яки квартиралы булу уңае белән тәбрикләү (йола буенча, гадәттә, бүләк бирелә). — *Кайда, күлмәгең котлап, нәрсә генә бирим соң? — дип, чәй янына куелган --- сыйлар арасында сайлана башлады.* М. Әмир. *Өй котладык, Гаҗәп шәп булды! Җырлап узды бәйрәм дигәнең.* З. Нури.

2. Хуплау, яхшы дип табу. — *Иптәшләр тарафыннан дружина төзү турында ясалган тәкъдимне авыл Советы һәм партия ячейкасы исеменнән котлап каршы алабыз.* Ш. Камал. — *Мондый ялкынлы дуслыкны котлыйм гына мин.* Р. Ишморат.

КОТЛЕТ *и. махс.* Ит яки балык фаршын озынча түгәрәк көлчә формасында кыздырып (яки парда пешереп) әзерләнгән ашамлык. *Без аш белән котлет [сорадык].* Н. Фәттах. || Яшелчә яки боткадан әзерләнгән шундый ук ашамлык. *Бу минутта ул гармонен сатарга да, ит, ипи, бәрәңге котлеты алып, түганчы ашарга уйлады.* Г. Гобәй.

КОТЛОВАН *и.* Берәр корылманың фундаментын салу өчен әзерләнгән зур чокыр, казан. *Бервакыт, насос станциясе өчен котлован казыганда, җир астыннан чыккан су чокырны басты.* Ш. Бикчурин. *Икенче энем — шофер, котлованга бетон ташый.* М. Хөсәен.

КОТЛЫ *с. иск.* **1.** Матур; ягымлы, сөйкемле. [*Нужа бабай:*] *Болар яши бузғысыз, Тол хатын да нужасыз, Бар да мине дошман күрә, Бар да котлы, мин котсыз.* Н. Исәнбәт.

2. Бәхетле. *Аның янында кичкән котлы көндә, гаҗәп ләззәтле төшләр күрдем өндә.* Дәрдмәнд.

◇ **Котлы булсын** — нинди дә булса эшне котлау, хуплау, изге теләк теләгәндә әйтелә: бәхетле булсын; уңышлы булсын. *Матур икән уйларың, Котлы булсын туйларың.* М. Җәлил. *Котлы булсын сабан туе, Уңсын ашлык булып куе, Сезнең белән безнең дуслык Китсен гомер-гомер буе.* Н. Исәнбәт.

КОТЛЫК *и.* Уңыш, бәхет. *Кыз үссә — кытлык, ул үссә — котлык.* Мәкаль.

КОТО'МКА *и сөйл.* Аркага асыла торган юл капчыгы; биштәр. *Котомкасын Үзе белән нигә алганын Төшенеп җитмим әле.* С. Хәким.

КОТО'МКАЛЫ *с.* Котомка аскан, аркасына котомка асып юлга чыккан юлчы. *Амбар тирәсенә котомкалы, фанер чемоданлы кешеләр, атлы олаулар килеп тулган.* Г. Ахунов.

КОТОЧКЫЧ *с.* **1.** Кот (1 мәгъ.), җан чыгарлык, бик куркынычлы, дәһшәтле. *Коточкыч бер хәлгә тарыган, Күренеп тора аның йөзеннән.* З. Мансур. *Әле генә коточкыч үлем давылы уйнаган сугыш мәйданын берьюлы тынлык басты.* А. Әхмәт.

2. Бик көчле, бик каты. *Иртәгесен очкычлар килер дигәндә генә, коточкыч бураннлы давыл кузгалды.* А. Алиш. — *Коточкыч суык җибәрә торган иләмсез станцияләр салганнар, ди.* Т. Гыйззәт. | *рәв. мәгъ. Аның мие сызлый, коточкыч авырттырып колаклары шаулый, әйтерсең, башын өзлексез утта кыздырып торалар.* Г. Бәширов. || Бик зур, чиктән ашкан. *Коточкыч хәсрәттән көеп, янып беткән йөрәктә кайдан бу кадәрле олы җылылык?!* Г. Әпсәләмов. *Янар тау авызыннан коточкыч көч белән шаулап күтәрелгән таш яңгыры шикелле снаряд кыйпылчыклары, үз юлларындагы коймаларны, стеналарны, тәрәзәләрне ватып, яндырып узалар.* К. Нәҗми. || Бик начар, яман. — *Габдулла әфәнде, мәдрәсәне яптырасыз бит! Коточкыч эш эшләгәнсез бит! — дип ярсынды Хәмидулла абзый.* Ә. Фәйзи.

3. *рәв.* Бик, артык. *Менә шушы коточкыч авыр унбиш көнне уздыру Җамали өчен унбиш ел гомер уздыру кадәр тоелды.* М. Гали. *Күлләгәм коточкыч озын булып сузылган.* Ф. Хөсни.

КОТОЧЫРГЫЧ *с. к.* коточкыч. *Һәр тарафта коточыргыч юлбарыслар котыра.* Һ. Такташ. *Мин бу коточыргыч зәһәр сүзле карчыктан котылырга ашыктым.* Ф. Әмирхан.

КОТСЫЗ *с.* **1.** Ямьсез, иләмсез, шыксыз. *Шатланып, иблис күзе ялт-йолт итә, Һәм дә котсыз койрыгы шап-шап итә.* Ш. Бабич. *Әллә ничек менә үземне котсыз, килбәтсез, ә өс-башымны ярлы, начар итеп тойгандай булдым.* Ә. Еники. || *күч.* Коточкыч, курку сала торган. — *Куй, куй, улым, мондый котсыз сүзләр сөйләмә.* Т. Гыйззәт.

2. Начар, яман; коты, иманы булмаган. *Илен саткан котсыз адәм, Һаман юкмы синең тәүбәң?* Н. Исәнбәт.

3. Коточкыч, бик көчле, зәһәр. *Котсыз суык көнне Шыксыз бүлмәмә син яз китердең.* Р. Фәйзуллин.

КОТСЫЗЛАНДЫРУ *ф.* Ямьсезләндерү, иләмсез, шыксыз итү (яки күрсәтү). *Йөзен болай да ямьсезләтеп торган шадралары аны хәзер бөтенләй котсызландырып күрсәтә иде.* А. Расих.

КОТСЫЗЛАНУ *ф.* Ямьсезләнү, иләмсезләнү, шыксызлану; ямьсез төс алу.

КОТСЫЗЛЫК *и.* Ямьсезлек, шыксызлык. || *күч.* Хәшәрәт; яман нәрсә. *Әйтерсең, тигәнәк, сырганак*

кыяфәтендәрәк шундый бер котсызлык инде аңа ябышып та өлгергән. Р. Төхфәтуллин.

КОТТЕДЖ *и.* Шәһәрдән читтә, матур табигать кочагына салынган, яхшы җиһазландырылган, җыйнак, гадәттә бер семьялык өй. *Коттеджлар алдына үсеп чыккан бөдрә өрәңгеләр --- тулышып утырдылар.* Г. Ахунов.

КОТЧЫККЫЧ *с. к.* коточкыч. *Кара чыршыларның берсе котчыккыч чиркәнеч тавыш белән шыгырдап ала.* М. Мәһдиев. *Котчыккыч хурлыклы аптыраш иде бу.* М. Әмир.

КОТЫЙЧЫК *и.* Кечкенә тартма, шкатулка, савыт (гадәттә агачтан эшләнгән була). *Тартма өстендәге котыйчыкны санамаганда, „яшел бүлмәдә" башка берни юк иде.* Н. Фәттах. *Ишек алдының түрендә котыйчык шикелле кечкенә ике өй бар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КОТЫЛГЫСЫЗ *с.* Эшләми калу, читләтеп үтү яки котылып калу мөмкин булмаган. *Дошман снаряды тиеп, танкыбыз яна башлады... Танк эчендә бер минут калу котылгысыз үлем иде.* Р. Ишморат. *Иртәме-соңмы алга килеп басарга тиеш булган бу котылгысыз мәсьәләне [Айдар белән Халидәнең бердәнбер яшәү мәсьәләсен] күрмәмешкә сабышып уздыралар.* Ф. Хөсни.

КОТЫЛГЫСЫЗЛЫК *и.* Котылгысыз булу. *Кискен бәрелешнең котылгысызлыгы июнь --- көннәрендә үк билгеле иде.* К. Нәҗми.

КОТЫЛГЫЧ *с.* Коткара, авыр хәлдән чыгуга, котылуга илтә торган. *Өе бер генә булып, бала-чагасы ишле кешегә бу мәдрәсә дигәнең бик уңайлы котылгыч урындыр, ахры.* Ш. Маннур.

КОТЫЛДЫРУ *ф.* **1.** Коткару; йолып алу. *Авыл хуҗалыгы артеле аның өчен тормышның бөтен җәфаларыннан, азапларыннан котылдырачак бердәнбер юл идә.* Г. Ибраһимов. *Игенчене элеккедәй күктән яңгыр көтеп уфылдаулардан котылдырасым килә.* Г. Бәширов.

2. Әләккән җирдән тартып алу, ычкындыру. *Хөршит җәһәт кенә йөзен күтәрде, турайды, йомшак, ләкин җитез генә хәрәкәт белән кулын минем учымнан котылдырды.* Ф. Әмирхан.

КОТЫЛУ *ф.* **1.** Башка төшкән бәладән арыну, куркыныч, авыр хәлдән һ. б. чыгу. *Бу кабердән котылса, ул монда артык бер көн дә тормас иде.* И. Гази. *Аллага шөкер, без хәзер ачлык тырнагыннан котылдык.* Т. Гыйззәт. || Азат булу, ирексезлектән чыгу, ирекле булу. [*Сандугач:*] *Яз җитә бит, нигә карамыйсың Читлегеңнән котылу чарасын!* Ш. Бабич. || Берәр тискәре гадәттән, начар холыктан, яман эштән арыну. *Көчле булды дару, егет күңеле ике чирдән бергә котылды.* М. Җәлил. [*Нәфисә*] *яшь киленнәргә хас оялчанлыктан котыла барып, хәзер үзендә комсомол эшендә чагындагы кыюлыкның яңадан кабынып китүен тоя.* Г. Бәширов.

2. Куркынычтан сакланып калу. *Ак бандитларның мәсхәрәләвеннән котылырга теләп урманда яшеренүче хатыннар күптән таралсалар да, Минзифа кайтырга ашыкмады.* К. Нәҗми. — *Менә шул чагында син дә, әткәй дә иртәгә булачак аресттан котылырсыз.* Т. Гыйззәт. || Янгын, йорт-җир, тау-таш җимерелү, суга бату һ. б. һәлакәт, афәт вакытында исән калу, үзен саклап алып калу. *Һәлакәт булганда экспедиция башлыгы иң соңгы булып котыла, бу — гадәт, закон булып тотыла.* А. Алиш || *Юкл. форм.* **Котылмау.** Бер-бер начар яки куркыныч хәлгә тару, шуннан читтә калмау. *Сугыштан балалар да котылмады.* Г. Ибраһимов.

3. Ычкыну, тотылган, әләккән җирдән качу. *Акбүз, чанадан котылып, тәрәзәдән мәктәп эченә ташланды.* Г. Гобәй. [*Бандит*] *Хәлимнән котылырга теләп, аны буарга, тешләргә, чәйнәргә тотынды.* А. Шамов.

4. Көтелгән зур җәза яки күп чыгым урынына кечкенә җәза яки аз чыгым белән чикләнү. — *Атыңны гына биреп котылуың өчен рәхмәт әйт, теләсәм, мин сине багана башына да күтәртә алам.* И. Гази. *Боларның берсе [Сәләхи], һөҗүмнең кинәт искәрмәстән ясалуы аркасында, үлем дәрәҗәсендә бик каты яралана, икенчесе [Мәдинә] --- җиңелрәк яралану белән котыла.* Ш. Камал.

5. *йск.* Солдатка алынмау, хәрби хезмәткә яраксыз табылу. [*Гайнавал:*] *Котылдыңмы, Мироныч?* [*Артамонов:*] *Алты айга калдырдылар.* Т. Гыйззәт. *Сердәш апасының бәхете ачылды, аның Закиры солдаттан котылды, шул елны туй ясап, Фатихәне аңа кияүгә бирделәр.* Г. Ибраһимов.

6. *сөйл.* Бала табу, бозаулау, колынлау һ. б. турында. *Ул чакта Флора йөкле иде әле. Ә хәзер инде менә котылган. Кыз бала.* Э. Касыймов. *Мәнә Кәримәнең „Алма"сы [сыеры], шөкер хода, исән-имин котылды.* Ә. Еники.

КОТЫП *и.* Җир шарының „күчәр очы" дип уйланылган ноктасы һәм шул тирәдәге урын; полюс (1 мәгъ.). *Төньяк котып, Көньяк котып.* □ *1912 елны ук Франс-Иосиф җире Россиянең котып тикшерүчесе Седовны үзенә тарта.* А. Алиш. | *с. мәгъ. Котып җиле тиле, Котып җиле кире, Усал, тискәре.* М. Җәлил. *Ә синең бит халкың сөю нуры Котып төннәрен дә җылыта.* Ш. Маннур. || *күч.* Нәрсәнең дә булса капма-каршы ягы, чиге. *Әйтерсең, врач тормышы шушы мәгърип-мәшрикътән [уңыш һәм уңышсызлыктан] гына тора. Әйтерсең, шушы ике котып арасында бернәрсә дә юк.* Г. Әпсәләмов.

КОТЫПЧЫ *и.* Котыпка ясалган экспедицияләрдә катнашучы, котып станцияләрендә эшләүче. *Николай Кожанов, --- котыпчылар кия торган бүреген --- киеп, буровойларга чыгып китә.* Г. Ахунов.

КОТЫРГАН *с* **1.** Тиле, акылын җуйган, психик авырулы; котыру авырулы. *Галләметдин --- котырган кеше төсле як-ягына карана башлады.* Ш. Камал. *Котырган эт, я котырган бүре Бер ташлана икән өстеңә, Мангаена атып, миен чәчрәтмичә Котылуны көтмә исеңә.* Ф. Кәрим.

2. Ярсу, ярсулы, үзен-үзе белештермәс дәрәҗәгә җитеп ярсыган, шашынган. *„Кызган, котырган халык әнине кыйнап ташламасалар ярар иде" дип курка башлады.* М. Гафури.

◇ **Котырган сыер сөте** — аракы, гомумән исерткеч эчемлек. — *Менә нәрсә, Николай: минем исемгә складтан [тиз] генә продукты яздырып ал. Кунак сыйларга. Котырган сыер сөте булса, аны да кыстырып кил.* И. Гази. **Котырган эт** — бер дә җайга килми, башкаларны җәберли, кимсетә торган кеше. — *Юк, юк, ул котырган эт белән алыш-бирешне өзәргә кирәк булыр.* К. Тинчурин.

КОТЫРМА *с. сөйл.* Котырып, ярсып торган. [*Буран*] *көн котырды, төн котырды. Шул котырма буранда калага барган җиреннән Дәүлинең аты кайтты, үзе юк.* Э. Касыймов.

КОТЫРТУ *ф.* **1.** Коткы салу, вәсвәсәләндерү. *Ният кылсаң котыртып йөргәләргә, Черетербез ябып куеп төрмәләргә.* Г. Камал. || Кешеләрне бер-берсенә яки берәр эшкә каршы күтәрү. [*Габдулла*] — *крестьяннарны колхозга каршы иң күп котыртып йөрүчеләрнең берсе.* Һ. Такташ. *Байлар, куштаннар --- [халыкны] Закир шикелле кыю егетләргә каршы котыртырга тырышалар.* М. Җәлил. || Мавыктыру. *Аз гына буш вакыт булган саен, [спорт белән] шөгыльләнәм. Бүлмәдәш егетләрне дә котыртып өлгердем.* Р. Төхфәтуллин.

2. Үртәү, үчекләү. *Тычкан балалары --- йөгерешеп йөреп, песи баласын котырткаННар.* А. Алиш. *Кирәкмәгән вакытта яудырып маташмасын, — диләр алар, аллага ышанучыларны котыртып.* А. Шамов. || Ярсыту, канын кыздыру, комарландыру. *Эти безне ярыштырып, котыртып эшләтә. Янәсе, кем көчлерәк, кем чыгырны җитезрәк әйләндерә.* Э. Касыймов. || Ярсыту, тынычсызландыру. — *Казан тулы провокатор, — дип башлады Столяров, — кешеләрне котыртып, ярсытып, бәхәскә кертәләр дә, аннары милициягә тотып бирәләр.* И. Гази. || *күч.* Котырындыру, ярсытып, көчәйтеп җибәрү (табигать күренешләре, җансыз предметлар турында). *Бик иркенләп исәсең җир йөзендә, Котыртып болгатасың диңгезен дә.* Г. Тукай.

КОТЫРТЫК *и. сөйл. к.* коткы. — *Кеше котыртыгына кararга сез балалармыни.* Г. Ибраһимов.

КОТЫРУ I *и.* Гадәттә хайваннарда була торган йогышлы психик авыру. || Психопатия; акылның нормаль булмавы (авыру).

КОТЫРУ II *ф.* 1. Котыру чире белән авыру; акылын җую, тилерү; психик авыруга сабышу. *Бу бала тегүче картның котыруына --- сәбәп булганлык Мохтарның исендә калган.* Ш. Камал.

2. Ярсып китү, үзен-үзе белештермәү. *Солдат тәмам котырып, алпавытның гүрнәчәсенә барып керә дә, мәлгуньне хатын, бала-чагалары алдында буып үтерә.* Г. Гобәй. *Күзе-башы күрми, котырса.* Ш. Маннур. || Тузыну, ярсып ризасызлык белдерү. *Вахитов ипташ аларның котыруын тыныч кына елмаеп күзәтте дә, тамаклары карлыгып беткән буржуйларны тагын бер утлы табага бастырып --- чыгып китте.* К. Нәҗми.

3. *күч.* Ярсу; көчәеп китү, котырыну (табигать күренешләре, җансыз әйберләр турында). *Җил дә әкрен генә исми — давыл булып котыра; яңгыр да яварга тотынса, бөтен җирне су белән тутыра.* А. Алиш. *Шулай бер котырып, бер басылып ага ул [Агыйдел].* М. Әмир.

4. Үзен иркен, йөгәнсез тоту, башбаштаклану; ни теләсә, шуны эшләү (явызлык эшләү турында). *Кулаклар, аларның иярченнәре тәмам котырды бит хәзер.* Г. Гобәй. *Үч алды халыктан Дошманнар котырып, Тутырып төрмәгә, Җәзалап, үтереп.* Ә. Исхак.

5. *сөйл.* Шаяру; иркенләп, рәхәтләнеп уйнау (уеннның кызып китүе). [*Көй*] *дөнья туздырып, котырып йөргән малайларны да җиңеп, туктата.* Г. Ибраһимов.

6. *рәв. мәгъ.* **котырып.** Шәп, бик яхшы (үсемлекнең яхшы үсүе, уңуы турында). *Бик тә котырып уңды бит быел яшелчәләр.* М. Хәсәнов. *Баштарак, галәмәт шәп булды, игеннәр котырып үсә дип сөенгәннәр иде.* Э. Касыймов. || Бик шәп, кызу, тиз. *Ул үзен давыл тизлегендә котырып чапкан бер поезд өстендә упкынга очкан хәлдә күрә.* Г. Бәширов. *Машина тәгәрмәчләре котырып-котырып әйләнәләр иде.* Х. Садрый.

КОТЫРЫК *и. сөйл.* 1. Коткы, котырту. — *Зәйнәп синең котырык белән, Габдерахманга бармыйм дип, безгә карыша бит.* Ф. Әмирхан. [*Мансур*] *акфинНарның империалистлар котырыгы буенча башлаган авантюралары тар-мар ителү белән үк ялга кайтачагын язган иде.* Г. Әпсәләмов.

2. *сөйл.* Котыру авыруы; психик авыру, бума чир. *Котырыгы тоту.* || *с. мәгъ.* Котыру авырулы; котырган. *Ә биредә? [Фашистик Германиядә] Кан чәчрәгән төрмә битләренә, Канга баткан котырык этләре.* Ш. Маннур.

КОТЫРЫНГАН *с.* 1. *к.* котырган. *Маташмагыз юкка, котырынган этләр, Шуннан артык бер сүз Алалмассыз бездән.* Ә. Исхак. [*Тоткыннар*] *читлектә котырынган усал ерткыч җәнлекләр кебек шакылдатырга --- тотыналар.* Г. Ибраһимов.

2. Ярсу, дулаулы, көчле (табигать күренешләре, җансыз предметлар хакында). *Тирән траншеядан басып, котырынган буранга караган Газинур, көрәк сабына таянып, бер минут чамасы уйланып торды.* Г. Әпсәләмов.

3. Йөгәнсез; ярсуның, явызлыкның соң дәрәҗәсенә җиткән. *Котырынган контрреволюциянең ялан кылычына каршы ул үзенең муенын куйды.* Ф. Әмирхан. *Без Г. Камал әсәрләрендә кеше хакын ашап, симереп котырынган, йөгәнсезләнгән байларны --- күрәбез.* М. Гали.

КОТЫРЫНКЫ *с.* Көчле, ярсулы. *Дошманның котырынкы атакасын кире кайтару. Котырынкы спекуляция.*

КОТЫРЫНКЫЛЫК *и.* Котырыну, ярсу. *Аның иләмсез зур булып киңәйгән күз бәбәкләрендә котырынкылык уйнады, ирен почмакларында күбекләр кайнады.* Ш. Камал.

КОТЫРЫНУ *ф.* 1. Кемнең дә булса киңәшенә яки коткысына, котыртуына бирелү. — *Бервакыт хатын „бик матур була“ дигәч, котырынып, шушы мыегымны карага буяган идем.* Г. Камал. || Тилерү, берәр тиешсез, мәгънәсез эш белән мавыгу, акылсызлык, юләрлек эшләү. — *Әллә тагын сугышка барам дип котырына микән.* Ш. Мөхәммәдев. — *Шәкерт бәдбәхетләр котырынуы һич тә кирәк эш түгел.* Ф. Әмирхан.

2. Ярсу, үзен-үзе белештермәү дәрәҗәсендә тузыну, шашыну. — *Нәрсә котырынасың тагы, нәрсә бар шулкадәр?* Р. Ишморат. [*Сафа Рәүфәнең*] *яңагына ике мәртәбә бик каты сукты да, шашып, котырынып, келәшчәдәй бармаклары белән муеныннан буарга тотынды.* А. Шамов.

3. Ярсып, көчәеп китү (табигать күренешләре һәм җансыз предметлар турында). *Акчишмә суының котырынып ярларыннан чыкканын хәтерлим.* К. Тинчурин. *Кар оча, кар себерелә, кар котырына һәм кар ява.* Г. Тукай.

4. Йөгәнсезләнү, ни теләсә шуны эшләү (явызлык эшләү). *Котырынган бу авылда фриц палачлары.* Ф. Кәрим. *Хәзер герман фашистлары котырына, самурайлар кылыч уйната, финнар кыбырҗый.* Г. Әпсәләмов.

5. *рәв. функ.* **котырынып.** Бик тиз; көчле рәвештә. *Әйберләрнең бәяләре котырынып үсә.* Ш. Камал.

КОТЫРЫШУ *ф.* 1. Котыру, ярсып шаулашу. — *Тик тор син, кара йөз! — дип шаулаша, котырыша башладылар.* М. Гафури.

2. *сөйл.* Уйнау, шаяру (берничә кеше бергә). *Капка төбе тулы бала-чага. Котырышалар.*

КО'ФЕ *и.* 1. Тропик якларда үсә торган куак агач һәм аның орлыгы. *1669 елда төрек солтанының Париж илчесе Сөләйман дигән кеше ундүртенче Людовикка күплəп кофе бүләк итеп китерә. Шуннан башлап Парижда кафелар ачыла башлый.* Г. Гали.

2. Эчемлек кайнату өчен кыздырып төелгән кофе орлыгы. *Син минем сумкамнан кофены ал да шуны кайнатып кына бир әле.* Г. Ибраһимов.

3. Төелгән кофе орлыгыннан яки аның башка нәрсәләр белән катнашмасыннан сөт, шикәр һ. б. лар кушып әзерләнгән эчемлек. *Вокзалда бер стакан кофе эчкәч, --- Галиевләрнең йортына килдем.* Г. Тукай.

КОФЕИН *и.* Кофе орлыгы яки чәй яфрагыннан ясала торган наркотик матдә. || *мед.* Шуннан эшләп-

гән дару (сулыш алуны, кан йөрешен көчәйтү өчен кулланыла). [*Гөлшаһидә*] *Исмәткә кофеин белән камфара уколы ясады.* Г. Әпсәләмов.

КОФЕИНЛЫ *с.* Кофеин катнашкан, составында кофеин булган. *Кофеинлы сода.*

КОФЕ'ЙНИК *и.* Кофе чәйнеге, кофе кайната торган чәйнек. *Нәфисә кофейник чыгарып куя, савыт-саба хәзерли.* Ә. Фәйзи.

КОФЕ'ЙНИЦА *и.* 1. Кофе тарту, төю жайланмасы, кофе тегермәне.

2. Кофе тартмасы, кофе саклана торган ябык савыт.

КОФЕХАНӘ *и. иск. к.* кафе.

КО'ФТА *и.* Билгә кадәр итеп тегелгән (яки бәйләнгән) хатын-кызлар киеме. *Ул кофта һәм юбкаларының материяләрен кулы белән капшап вә бик дикъкатьләп карады.* Ф. Әмирхан.

КО'ФТОЧКА *и.* Юка материядән тегелгән кофта. *Гөлсем апа аны бераздан, үзенең ак кофточкасын киертеп, шәленә төреп күтәрде дә тагын вокзалга --- алып китте.* Г. Гобәй.

КОХ: кох таякчыклары *мед.* — туберкулез авыруын тудыра торган микроблар.

КОХ-БАЦИ'ЛЛА *и. мед. к.* кох таякчыклары. *Ул берсенә тиф вакцины биргән, Кох-бацилла икенчесенә.* Х. Камалов.

КОЧАК *и.* 1. Кулларның якын кешеңне иркәләп һәм сөеп күкрәккә кыскандагы торышы. *Ире, үзенең көчле кочакларына алып, күкрәгенә кыскан чагында, Нәгыймә аның йөрәк тибүләрен үз тәнендә тоя.* Г. Ибраһимов. [*Бала*] *әнкәсенең кочагына үптерер өчен атыла, әткәсенә башыннан сыйпатыр өчен омтыла.* Ш. Камал.

2. Берәр әйберне уратып кулларны бергә тоташтырган колач. *Сөембикә апа әйтә, монда, ди, менә мондый кочак җитмәс кабаклар үсәр, ди.* Ә. Еники.

3. Берәр әйбернең кочаклап бер күтәрергә житәрлек, бер кочакка сыешлы күләме. *Бала-чага төркеме бер кочак саламга ут төртеп ташуга агызып җибәрә.* Г. Бәширов. || *күч.* Бик күп. *Бер кочак хәбәр. Бер кочак яңалык.* □ *Кичәгедәй бер кочак хат Күн сумкада, куенында.* М. Җәлил.

4. Кочакның яртысы, бер кул белән ясалган кочак. [*Карчык*] *ылысларын уң кочагыннан сулына күчерде дә, башын мәет яткан ишеккә таба ия-ия, ике-өч тапкыр чукынып алды.* Г. Гобәй. [*Миңнурый*] *ишек алдында бауга эленгән керләрне кочагына җыеп йөри.* Г. Әпсәләмов.

5. *күч. к.* куен 2. *Шундый иртә яшь кәләш кочагыннан торып йөрергә ни пычагым калгандыр аңа.* Ә. Еники.

6. *күч.* Кул (асты), карамак, ара. *Коммунадан да чыгарып ташласак, без аны* [*Нәгыймне*] *баш-аягы белән кулаклар кочагына биргән булыр идек.* Ш. Камал.

7. *күч. шигъ.* Табигатьне, җир өстен белдергән сүзләр янында: шул урынның чолганышы, түре (киңлек, иркенлек, рәхәт-хозурлык символы буларак кулланыла). [*Кырлайда Тукайга*] *өйдән чыкса, матур һәм юмарт табигать кочагы, өйгә кайтса ягымлы чырай, җылы сүз.* Ә. Фәйзи. *Болын кочагында мин аунадым, Мин гөлләрне сиңа тиңләдем.* Ә. Ерикәй. *Җәйрәп яткан Идел кочагында талгын гына йөзә пароход.* З. Мансур. || Җир, су, караңгылык һ. б. турында. *Озата килүче кеше төн кочагына кереп югалырга да өлгермәде, өч кеше --- камышлар эченә кереп югалдылар.* И. Гази. — *Минем Пятрасым да шулай кайда да булса салкын җир кочагында ята торгандыр, — дип уйлый.* А. Шамов. *Бер төн шулай --- Төрмә кочагына салдылар.* Ф. Кәрим. || Иркәләү, сөю, ягымлылык символы. *Мин тагын, Сакай авылына барып, сөекле анам янында, аның шәфкатьле кочагында тора башладым.* М. Гафури.

Кочагына алу — кочаклау. *Егет, яңадан кочагына алып, Сылуның тулы канлы, карасу кызгылт иреннәреннән үпте.* Г. Ибраһимов.

◇ **Кочагын ачып тору** — үзе көтеп тору, әзерләнеп тору. [*Карт Зифага:*] *Бәхетең кочагын ачып тора. Син аннан качасың икән.* М. Фәйзи. **Кочак җәеп каршы алу** — дусларча, үз итеп кабул итү, көтеп каршы алу. *Чабаталы кара эшче яшьне монда Кочак җәеп каршы алдылар.* М. Җәлил.

КОЧАКЛАНЫШУ *ф. к.* кочаклашу. *Тукмар да Чукмарны бик сагынган булган, алар күптәннән бирле күрешмәгән туганнар төсле кочакланышып күрешкәннәр.* А. Алиш. [*Илдус белән Ирек*] *кочаклашкан килеш килеп керәләр.* Д. Аппакова.

КОЧАКЛАУ *ф.* 1. Иркәләү, сөю өчен куллар белән урап алып кысу, кочакка алу. *Газиз кочакларга тели, кыймый. Рәхимә уңайсызлана.* А. Әхмәт. [*Хәсән*], *пароходтан чыгуга, иң элек Зәйтүнәне кочаклап алды.* К. Нәҗми.

2. Нәрсәне дә булса кочакка алып күтәрү. *Ул арада Мөхәммәтҗан бабай, каезлаган юкә кочаклап, урманнан килеп тә чыга.* М. Гали. [*Газинур*] *печән чүмәләсе кочаклап китергән шикелле, ботаклар кочаклап килгән чая кызларга шаян сүзләр кычкыра.* Г. Әпсәләмов. || Бер яки ике кул белән күкрәккә кысып тоту. *Берәүгә дә күтәрелеп карамастан, әлеге дәфтәрне кочаклап, теге ак чырайлы военврач янына барам.* Ф. Хөсни. [*Солдат*] *автоматын кочаклаган килеш караңгылык эченә кереп югалды.* Ә. Айдар. || *күч.* Кочакка сыймаслык әйберләрне колачлау. *Анабыз җирне кочаклап Бәлки үләрмен.* Ф. Кәрим. *Йөрәгендә шундый зур шатлык, күңеле шундый якты, әйтерсең бер үзе бөтен дөньяны кочаклаган.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Үз эченә алу (табигать һәм аның күренешләре турында). *Дулкыннар, аны кочаклап алалар да, ашыктырып-ашыктырып үзләре белән түбән таба алып китәләр.* Г. Ибраһимов. *Ә безне инде, аю баласыдай, Кочаклады калын тайгалар.* Ш. Маннур.

КОЧАКЛАШУ *ф.* Бер-берсен кочаклау, кочакка алу. *Ике туган бер җан, бер тән булып кочаклаштылар да, әниләре ишетмәсен өчен, әкрен генә елыйелый, берсен-берсе юата-юата йокыга таләдылар.* Г. Гобәй. *Алар бер-берсен күптән, бик күптән күрмәгән төсле кочаклаштылар.* А. Алиш. || Ике яки берничә кешенең берәр кул белән генә бер-берсен кочуы, ягъни бер кул белән җилкәсеннән яки биленнән алу. *Малайлар --- биллэреннән алышып кочаклаштылар да, бөтен тыкрыкны иңләтеп, җырлый-җырлый Иделгә төшеп киттеләр.* М. Әмир. || *күч.* Бергә кушылу, тоташу (җансыз әйберләр турында). *Җилем суы --- шул матур тугайларның иң матур җиренда Агыйдел белән кочаклаша.* М. Гафури.

КОЧЕГАР *и.* Кочегаркада эшләүче. *Гали исемендәге бу адәм, уникә елдан бирле Искәндәр байның паровой он тегермәнендә кочегар булып хезмәт итеп, җәмәгатьләрен тәрбия кылд иде.* Ш. Мөхәммәдев.

КОЧЕГА'РКА *и.* Пар казаннарына ягып тору бүлмәсе, гомумән ягып җылыту яки машиналарны пар белән хәрәкәткә китерү системасында ягып тору урыны. *Зур тәрәзәдән кочегарка моржалары һәм рудник корпусы күренеп тора.* Ш. Камал.

КОЧУ *ф.* 1. Кочаклау, кочакка алу. *Аны* [*Рәүфәне*] *хәзер барыннан да бигрәк бу кешенең сүзсезлеге, шашынып үбүе, озын куллары белән урап алып кочуы куркыта иде.* А. Шамов. *Ул әкрен генә хатыны янына килде, аның иңбашларыннан җиңелчә генә*

кочып алды. Г. Әпсәләмов. || *күч.* Колачка сыймаслык әйберләр турында. *Тормышка яшьләрчә масаеп карап, ул бөтен дөньяны берьюлы кочмакчы булып йөри.* И. Гази.

2. *күч.* Үз кочагына, үз эченә алу (табигать, үлем һ. б.). *Ләкин күптән инде мескенне Салкын юеш кабер кочкандыр.* Ф. Бурнаш. *Үлем коча көрәш солдатының Бүген менә сирәк санлысын.* М. Җәлил.

КОЧЫШУ *ф. к.* Кочаклашу. *Минем дә яратасым, яраткан кешем белән --- тын беткәнче кочышасым килде.* Г. Кутуй.

КОШ *и.* **1.** Тәне йон-мамык һәм каурый белән капланган, һавада очу, җирдә йөрү, кайберләре суда йөзү өчен дә җайлашкан, ике канатлы һәм томшыклы, җылы канлы, умырткалы жан иясе. *Кош тик канатларым булса, Кайтыр идем күрергә.* Җыр. *Иң матур кош җирдә — тавис...* Ф. Кәрим. || *күч.* Очкыч; самолет яки аэроплан. *Корычканат дигән кошка атланып очты.* А. Алиш. *Телисең икән самолетка утырасың. Бик шәп җиһазланган ул көчле һава кошлары сине --- әллә кайларга илтеп куялар.* Г. Бәширов.

2. *күч. сөйл. ирон.* Кеше (аңа холкы, характеры, җәмгыятьтәге урыны, дәрәҗәсе, эшенә һ. б. карап бирелгән бәя). *Үз күзебез белән күрик, белик, нинди кош икән ул сәүдәгәр [Низами турында].* М. Әмир. *Безгә „тел" әләктерергә кирәк. Зуррак берәр „кошны" кулга төшерергә кирәк.* Ә. Айдар.

Кош теле — 1) *махс.* йомыркага баскан ак он камыры җәймәсен тел формасындарак (өчпочмак яки ромбыга охшаш) кискәләп, майда пешерелгән, чәй янына куела торган ашамлык. *Чәк-чәк, кош теле, юача, әлбә, савыт белән кәрәзле бал һәм башка төрле сыйлар килеп чыкты.* М. Гали; 2) кечкенә генә хат; язу. *[Йөзлебикә:] Анда [китап эчендә] кечтеки генә бер кош теле дә бар бугай... Хәер, кош теле дигәне дә берничә юл Такташ шигыре генә иде бугай.* Г. Бәширов.

◇ **Кош кебек (коштай) очу** — бик тиз, шәп бару (йөгерү, чабу). *Гафиятулла абзый сулы мичкәсе белән анда кош кебек очып барып җитте.* Г. Әпсәләмов. *Кызлар, мин киттем, Атым, коштай оч!* Ф. Кәрим. **Кош очмаслык** — бик көчле, зәһәр (салкын, буран). *Кош очмаслык салкыннар башлану.* **Кош очып җитмәс(лек)** — бик ерак. *Кошлар очып җитмәс җиргә китә газиз башыбыз.* Җыр. **Кош тоткандай** — бик шатланып, үзеңне бәхетле сизеп. *Китапны алдым да, кош тоткандай булып, [кибеттән] чыгып киттем.* З. Бәшири. **Кош өлеше** *иск.* — басуда урмыйча, кош-корт чүпләр өчен калдырылган ашлык. *Кош өлеше калдырган фәкыйрьгә гошер бирмәсә дә ярый.* Мәкаль.

КОШЁВКА *и.* Артлы чананың бер төре: артка ике кеше аркасын терәп утырырлык, алда ат тотучы өчен урын көйләнгән көймәле җиңел чана. *Малик үзе кошевкага утырып, бераз соңрак кузгалды.* И. Гази.

КОШЕВОЙ: кошевой чана — *к.* кошевка. *Хәдичә яхшы кошевой чана янында иде инде.* М. Хәсәнов.

КОШЕНИЛЬ *и.* Кызыл төстәге каты кабыклы бөҗәк һәм шул бөҗәктән алына торган буяу матдәсе; ул кармин дип аталган җете кызыл буяу ясауга китә (СССРда Әрмәнстан, Украина һәм Белоруссиядә очрый).

КОШ-КОРТ *җый. и.* Йорт кошлары. *Мостафиның, мәгълүм булганча, йорты бар, йортында сыеры бар, кош-кортлары бар.* Ә. Еники. || Һәртөрле киек кошлар, вак җанварлар. *Нинди ел булгандыр ул, белмим — җәнлекләр, кош-кортлар шулкадәр күп иде, мылтык астына үзләре килеп керәләр иде.* А. Шамов. *Барча кош-корт йоклаган булганга, урман тын икән.* Г. Тукай.

КОШКУНМАС *и. диал. к.* эт шомырты. — *Д кошкунмас агачын беләсезме сез?* Марс Шабаев.

КОШТАБАК *и.* Бер литр чамасы сыйдырышлы агач яки калай тирән тәлинкә; кечкенә табак. *Гашия, кечкенә коштабакка сосылган тары боткасы күтәреп, аралыктан килеп тә чыкты.* М. Әмир.

КОШЧЫ *и.* Кош фермасында эшләүче, кош караучы. *Уңган кошчы [Г. Закирова] --- дәүләткә 18 мең йомырка озатты инде.* Соц. Тат. *Кечкенә, җыйнак кына булган кошчылар өчен керделәр.* С. Рафиков.

КОШЧЫК *и.* **1.** Кечкенә кош. *Чакырсам да, кошчык, Син бу йортка [төрмәгә] Үзең теләп очып кермәссең.* М. Җәлил. *Җырлый кошчык, дәтерсең лә, дөнья Тик бер аның өчен яралган.* З. Мансур. || Кош баласы. *Балалар ятим кошчыклар белән шулкадәр мавыктылар.* Г. Гобәй.

2. *тарт. форм.* **кошчыгым.** Иркәләп эндәшү сүзе. *„Кошчыгым, хәтерлисеңме, кәккүк ни диде?" — дим. Кошчыгым минем — нурлы иртә хөрмәтенә мин иркәмне шулай дип атарга өйрәндем.* Ә. Еники.

КОШЧЫЛЫК *и.* Терлекчелекнең бер тармагы буларак, йорт кошлары асрау хуҗалыгы. *Кошчылыкта эшләү.* || *с. мәгъ.* Шундый хуҗалык урнашкан, кошлар асрый торган. *Авыл башындагы кошчылык фермасында меңгә якын тавык һәм ун-унбиш этәч яши иде.* Г. Галиев. *Сарык фермасы белән янәшә, инеш буенда, кошчылык фермасы.* А. Әхмәт.

КОЭФФИЦИЕНТ *и.* **1.** *мат.* Алгебраик гамәлләрдә сан яки хәреф белән белдерелгән тапкырлаучы. || Аерым шартларда таләп ителгән зурлыкны табу өчен нинди дә булса бер зурлыкка тапкырланырга тиешле сан. — *Сез үзегезнең зур скреперыгыз белән туфракны 600 метрдан аласыз. Шуннан коэффициент та, төшем дә югары.* Г. Әпсәләмов.

2. *физ.* Физик җисемнең нинди дә булса үзенчәлеген билгели торган зурлык. *Ышкылу коэффициенты.*

КОЮ *ф.* **1.** Күпләп төшерү (үзеннән); нәрсәдән дә булса арыну (яфрак, чәчәк, каурый, йон, өлгергән җимеш, орлык һ. б. ш. турында). *Быел агач яфракларын үз вакытында койды.* Г. Бәширов. *Өзелеп сагындым каз канатын койган болыннарны...* Ш. Маннур. || Икенче бер әйбердән күпләп төшерү, коелдыру. — *Ай, тинтәкләр, такыя атып уйнамагыз, алмаларны коясыз дип әйттем ләбаса мин сезгә.* М. Фәйзи. || Мул итеп тарату, сибү, чәчү (нур, яктылык, һ. б. турында). *Кояш бертуктаусыз нурын коя.* Ә. Ерикәй. *Меңләп йолдыз --- җиргә сихерле яктылыклар коялар.* Ф. Әмирхан.

2. Бер урыннан (савыттан) икенчесенә сыек әйберне бушату, күпләп салу, агызу. *Икенче яктан шанга су коя торган трубаны насоска беркеттеләр.* Ш. Камал. *Графиннан башына су коюым белән, [немец офицеры] сикереп торды.* Ә. Айдар.

3. Вату, ваклап төшерү. *[Ибрайның] рогаткасы бер генә тәрәзәне коеп төшерми.* Г. Гобәй. *[Миңнур карт] бер шешә чыгарып, аның авызындагы сургучын коярга кереште.* А. Шамов.

4. Икенче бер елгага яки күлгә, диңгезгә килеп кушылу, агып төшү. *Безнең авылның буеннан аккан бу елга Өршәккә, Өршәк Димгә, Дим Агыйделгә коя.* Г. Ибраһимов. *Башта, диләр, Иделне тап --- Кама койган җирне тап!* Н. Исәнбәт.

5. Руданы эретеп, чуен, корыч һ. б. эшләү. *Комбайнны мехчы кызлар йөртми, зоотехник көймый корычны.* З. Мансур. || Металл яки руданы эретеп нәрсә дә булса ясау, билгеле бер формага салу. *Эшче дуслар корал койдылар.* Г. Хуҗи. *Бу ядрәгә кушып койган эшче йөрәгенең тирән ачуын.* М. Җәлил. || Томумән, төзү, салу, кору, эшләү. *Тату туганнар таштан койма койганнар.* Мәкаль. *Бакча гөл була-*

чак, өйне дә икенчене салачак, читән урынына койма коячак. И. Гази. || Әзерләү, ясау. *Былтыр койган алма какларын син, Чикләвекләр җыеп киптереп, Аларга! --- дип һаман саклыйсыңмы, Сагыш белән көтеп, тилмереп.* А. Алиш.

6. *күч.* Чиләктән койган, түккән кебек көчле һәм өзлексез яву (яңгыр турында). *Чиләкләп-чиләкләп яңгыр коя башлый.* Ә. Айдар. *Тышта көне буе яңгыр коя.* Г. Әпсәләмов. || *рәв. мәгъ.* **коеп.** Көчле, чиләктән койган кебек (яву). *Ява коеп яз яңгыры.* Дәрдмәнд. *Коеп-коеп яңгыр яварга тотынды.* Г. Нигъмәти.

◇ **Коеп куйган** — 1) нәкъ үзе (охшау, копиясе булу, шуның төсле яки чаклы булу турында). *Сиражиның хатыны Гөлҗиһан коеп куйган чеп-чи мещанка.* М. Гали. *Зур баласы — Хәсән. Бусы коеп куйган әткәсе.* Г. Ибраһимов; 2) нәкъ үзе, нәкъ шуна яраклы, бик кулай, туры килә торган. [*Акбирдин*] *безнең колхозга председательлеккә коеп куйган кебек инде.* К. Тинчурин. **Коеп куйгандай (кебек, шикелле, төсле)** — җыйнак, килешле, матур (коеп эшләнгән сынлы сәнгать әйберенә — скульптурага охшатыла). *Коеп куйган шикелле матур иҗнәре --- матур йөзнең гүзәл кушымталары.* Ф. Әмирхан. [*Вәсиләнең*] *биле сыгылып тора, буе-сыны коеп куйган төсле.* Ф. Хөсни. **Коеп кую** — бик оста, сыйфатлы һәм төгәл итеп эшләү турында. — *Син такта-токта эшенә мачтыр кеше. Кем әйтмешли, ясаган нәрсәңне коясың да куясың.* Ф. Яруллин.

КОЮХАНӘ *и. иск.* Хәреф кою мастерское. *1813 елдан башлап университет типографиясе янында гарәп хәрефе коюханәсе эшкә керешә.* И. Рәмиев.

КОЮЧЫ *и. махс.* Металл кою остасы, белгече.

КОЯШ *и.* **1.** Тирәсендә әйләнә торган Җир һ. б. планеталар өчен яктылык һәм җылылык чыганагы булган, кызган шар формасындагы күк җисеме. *Бар галәмнең җан чишмәсе — кояш.* Ш. Маннур. || *тарт. форм.* **кояшым.** Иркәләп кешегә эндәшү сүзе. [*Түләк:*] *Аембикәм минем, кояшым... Аһ, син үлдең, минем юлдашым!..* Н. Исәнбәт.

2. Кояштан килә торган нур, яктылык, җылылык. *Кояш яфраклар арасыннан челтәрләнеп Хәятның күзенә төште.* Ф. Әмирхан. *Җәйге көн, өсләренә кояш төшеп, Баралар юл буенча янып-пешеп.* М. Гафури.

3. *күч.* Яктылык, ирек, бәхет-шатлык чыганагы. *Якын күреп миңа кем дәшәр, Иң зур кояш булган дәүләтемә Җиңү белән рапорт бирмәсәм.* М. Җәлил. || *шигъ.* Газиз, кадерле, тормыш өчен иң кирәк булган нәрсә чыганагы — символик образ. *Гаделлек кояшы. Бәхет кояшы. Өмет кояшы.* || Төп яшаныч, өмет юнәлдерелгән кеше. — *Син... Син безнең кояш бит, Фазыл туган.* Г. Ибраһимов.

Кояш батышы (баешы) — *к.* көнбатыш. *Кояш чыгышы ягыннан исеп киткән йомшак җил игеннәрне кояш батышы ягына бөкрәйтте.* Ф. Әмирхан. *Булмасын икән ярларың кояш баешларында.* Җыр. **Кояш ваннасы** — тәнне кояш нурлары тәэсире белән дәвалау, чыныктыру процедурасы. **Кояш иңеше** — *к.* көнбатыш. *Кояш иңешендә, биек вә калын агачлар арасыннан гына кызыллы-сарылы офык күренә иде.* Ш. Камал. **Кояш системасы** — Кояш һәм аның әйләнәсендә хәрәкәт итүче планеталардан торган күк җисемнәре җыелмасы. *Җир кояш системасына керә.* **Кояш тажы** — тулысынча тотылган вакытта кояшның ай каплап бетерми калган якты бөжрасы, кояш атмосферасының тышкы өлеше. **Кояш торгынлыгы** — кояш җир эклиптикасының иң төньяктагы яки иң көньяктагы ноктасы аша уза торган вакыт. *Кышкы кояш торгынлыгы (иң кыска көн — 21-22 декабрь). Җәйге кояш торгынлыгы (иң озын көн — 21-22 июнь).* **Кояш тотылу** — кояш белән җир арасына ай килеп керү сәбәпле кояш нурларының җир өстенә төшмәве яки өлешчә генә төшүе. *Кояшның тотыла башлавыннан --- аптырап калган Мәрьям туташ та берьюлы айнып [китте].* Г. Ибраһимов. **Кояш чыгышы** — *к.* көнчыгыш. *Без барабыз сугышка, ерак кояш чыгышка, Патша өчен үлемгә барабыз без сугышка.* Ш. Мөхәммәдев.

◇ **Кояш ашау (алу)** — кояш нурлары тәэсирендә тәннең, әйбернең төсе үзгәрү — тән каралу, әйберләрнең төсе югалу, агару, уну. *Ап-ак итеп кершән сөртсәң, Битең кояш ашамас.* Г. Тукай. *Гыйззәт абый кояш алган гимнастерка чабуларын төзәтте.* Г. Гобәй. **Кояш белән бергә** — бик иртә, кояш чыккан вакытта. *Ул кояш белән бергә кузгала, көрәген ала, җиңен сызгана.* М. Җәлил. **Кояш иле** — кояш озак һәм нык җылыта, шунлыктан кышы да, салкыны да булмый торган як, җылы як. *Сәлам сиңа, кояш иле, Тугандаш ил Үзбәкстан!* Н. Исәнбәт. **Кояш кебек (шикелле, төсле) ачык** — 1) һәркемгә билгеле, мәгълүм; *к.* көн кебек ачык. *Кеше шундый кояш шикелле ачык нәрсәләрне аңламый азапланса, минем каным кыза башлый.* Ф. Әмирхан; 2) мөлаем, ягымлы (чырай турында). *Кояш кебек ачык чырай белән каршылау.* □ *Вәсилә чыкты. Чыкканда кояш төсле иде, мине күргәч бөтенләй коелып төште.* Ф. Хөсни. **Кояш сугу** — кызу сугу; кояш нурларының баш миен артык кыздыруы нәтиҗәсендә барлыкка килгән авыру. **Кояшы баю (бату)** — хуҗаларча иркен эш итү, яшәү мөмкинлекләре бетү. — *Дөрес, Муса, аларның [мирзаларның] кояшлары байый, ә безнең таңыбыз ата.* Ф. Бурнаш.

КОЯШЛАП *рәв.* Кояш белән, кояш барда. *Кояшлап яуган яңгырдан түгел, көлеп сөйләшкән егеттән түгел.* Мәкаль.

КОЯШЛЫ *с.* **1.** Кояш яктырткан, аяз. *Көндезен көн кояшлы, матур, җылы булуга карамастан, кичен суыта.* М. Гали. *Шундый кояшлы, сыерчыклы көннәрнең берендә авылга Якуб кайтты.* И. Гази. || Кояш нурлары мул төшкән, якты. *Кояшлы бакчада төрле-төрле күбәләкләр канат җәйде.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Бәхетле, якты тормышлы. *Без кояшлы илдән, һәм ул илдә Ял хокукы бөтен кешедә.* М. Җәлил.

Кояшлы яңгыр — кояш яктыртып торганда ява торган җылы яңгыр. *Кояшлы яңгыр сибәли, Ямьләп Идел буйларын.* З. Мансур.

КОЯ'ШТЫР *ы.* Сүзенең дөреслегенә яки вәгъдәсенең үтәләчәгенә ышандыру өчен ант итү сүзе булараk кулланыла: билләһи, валлаһи, икмәктер. *Авыл малайлары да аналарының бөрәр нәрсәсен сыптырып тотылгач: — Кояштыр, алмадым, диләр, кояшны якасыннан тотып шаһитлыкка өстериләр.* Һ. Такташ. — *Кояштыр, дип әйтәм, әгәр уңсам, Алып бирәм сезгә пар яулык.* Ш. Маннур.

КОҢГЫЗ *и.* Элпә канатлардан тыш каты канатлары да булган бөҗәк. *Май коңгызы. Бакыр коңгыз. Су коңгызы. Сасы коңгыз.* □ *Ара-тирә тәрәзә пыяласына вак коңгызлар килеп бәрелә.* Г. Бәширов.

КОҢГЫЛДАУ *ф. к.* гаңгылдау, гайгылдау. *Күк ата казның коңгылдавы яңгырап ала.* М. Мәһдиев.

КОҢГЫЛДАШУ *ф.* **1.** *к.* гаңгылдашу, гайгылдашу. **2.** *күч.* Шау-гөр килү, шаулашу. *Коңгылдашкан күп яманга хур булдым.* Мәкаль.

КОҢГЫР *с. сөйл. к.* коңгырт. *Михаилның коңгыр күзләре һаман очкын чәчеп торалар.* Ф. Әмирхан. [*Галләметдиннең*] *коңгыр сакалына байтак чал кергән.* Ш. Камал.

КОҢГЫРЛАНУ *ф. сөйл. к.* коңгыртлану. *Күк йөзендә каяндыр борын яулыгы хәтле генә ак болыт*

күренде. Аның янына тагын берсе килеп кушылып коңгырланды. Ф. Сәйфи-Казанлы.

КОҢГЫРЛЫК *и. сөйл. к.* коңгыртлык.

КОҢГЫРТ с. Карасу көрән төстәге. *Маяковский тора алгы сафта, куе коңгырт чәчен туздырып.* С. Хәким. || Башка төс атамалары янында килгәндә: коңгыртка тартым; коңгырт төсмере булган. *Кара чәчле, коңгырт кара күзле --- Ул, Мокамай бәгърем, син идең.* Һ. Такташ. *Бу сөйкемле кешенең исә коңгырт яшел күзләре сине кеше буларак сангa алып, хәтта якын итеп елмая.* Г. Бәширов.

КОҢГЫРТЛАНУ *ф.* Коңгырт төскә керү. *Көз көне Муса Кырымнан кайтып килде. Тагы да коңгыртлана-карая төшкән.* М. Максуд.

КОҢГЫРТЛЫК *и.* Коңгырт булу; коңгырт төс.

КПСС *и.* Советлар Союзы Коммунистлар партиясе (русча *Коммунистическая партия Советского Союза* тезмәсенең кыскармасы). *КПСС тарихы. КПСС членлыгына кандидат.*

КРАБ *и.* Кыска гәүдәле, ун аяклы диңгез кысласы. *Комбинат директоры Насыйров дзерләткәндер мең төрле консерв. Төрле-төрле балык, краб Торадыр авызга керүне сорап.* С. Баттал.

КРА'ГИ *и.* Күннән эшләнгән куныч, балтырга киелә торган аяк киеме. *Берсеннән-берсе баерак, елкылдап торган крагилардан, котелок я цилиндрлы --- фырт кавалерлар бакча аллеяларын тутырып гөр килеп йөриләр.* А. Расих.

КРАЙ *и.* 1. СССРда зур административ-территориаль берәмлек. *Ерак Көнчыгыш крае. Край башкарма комитеты.*

2. Урынчалык, билгеле бер өлкә, як. *Крайны өйрәнү түгәрәге.*

КРАЙКОМ *и.* Край (1 мәгъ.) комитеты. *Партия крайкомы.*

КРАКОВЯ'К *и.* Поляк милли биюе һәм шул биюгә язылган музыка. *Гыйльман граммофонда „Краковяк" көен уйната.* Г. Коләхметов.

КРАН I *и.* 1. Сыеклык яки газ тутырылган резервуардан (савыттан) бушату, агызу максаты белән труба аша тоташтырылган ачу-ябу җайланмасы. — [*Дошман*] *авылга керә башласа, керосин бакларының краннарын ачыгыз: тамчысы да дошманга эләкмәсен!* И. Гази.

2. Зур үткәргеч трубаларда сыеклыкны тоткарлап тору һәм агызу хезмәтен үти торган җайланма.

КРАН II *и. тех.* Авыр йөкләрне төяп бушату һәм күчерү механизмы, күтәрү краны. *Күктәрәк — гигант кран, Ыржаеп күренә Көрычтан тешләре.* Н. Исәнбәт. *Йолдызларга тигән Деррик краны Зур табаклы корыч элдергән.* Ш. Маннур.

КРАНЧЫ *с.* Күтәрү кранында эшләүче, кранны идарә итүче. *Кранчы булырга укырга килүем дә биеклекне яратудандыр, мөгаен.* Ф. Яруллин.

КРА'ТЕР *и.* Янар тау түбәсендә лава бәреп чыга торган уенты; янар тау авызы. *Әгәр парның этүе тагын да куәтләнсә, ул вакытта тауның башы тишелеп, анда „кратер" диелә торган юл хасил була.* Ф. Әмирхан.

КРАХМАЛ *и.* Үсемлекләрдә яктылык тәэсире белән барлыкка килә торган бөртексыман составлы органик матдә — углевод. *Башаклы ашлыкларның (бодай, арыш, кукуруз) орлыкларында крахмал күп була.* Ботаника. || Кайбер үсемлекләрдәге тәме булмаган ак порошок хәлендәге матдә (азык, химия һәм текстиль промышленностенда кулланыла). *Бәрәңге крахмалы. Дөге крахмалы.* □ [*Төлшәнидә*], *аклап бетергәч, крахмалдан җилем кайнатып, обойларын ябыштырды.* Г. Әпсәләмов.

КРАХМАЛЛАУ *ф.* Тукыманы (бигрәк тә ак төстәгесен) нык, тыгыз итү һәм ялтыравыклы ак төскә кертү өчен крахмал эремәсе салынган суга манып үтүкләү. *Җәймәләрне крахмаллау.* □ [*Җиһангир*] *Гүзәлдән ак яканы крахмаллатып алды.* Г. Гобәй.

КРАХМАЛЛЫ *с.* Крахмалга бай, составында крахмалы күп булган. *Арыш, бодай, кукуруз, борчак, бәрәңге һ. б. ш. крахмаллы азык санала.* || Крахмалланган, крахмал сеңдереп үтүкләнгән. *Элек ул крахмаллы ак яка, тройка костюм, өр-яңа шиблетләрне бар дип тә белми иде.* Г. Әпсәләмов.

КРАХМАЛЛЫЛЫК *и.* Крахмаллы булу дәрәҗәсе. *Кукуруз крахмаллылык ягыннан беренче урында тора: аның составында 68% крахмал һәм шикәр матдәсе бар.* Ботаника.

КРЕВЕ'ТКА *и.* Вак кына, ашарга яраклы диңгез кысласы. *Корея йөкчеләре күчтәнәч итеп безгә бер кәрзин креветка китерде.* Р. Мостафин.

КРЕ'ДИТ *и. махс.* Исәп-хисап кенәгәсенең чыгымнар языла торган ягы; *кирәсе*: дебет. *Конторщик Җиһангәрәй агай куркуыннан дәфтәрнең дебетенә язылачак бер хисапны кредитенә язып җибәргән.* Ш. Мөхәммәдев.

КРЕДИ'Т *и.* 1. Өлешләп түләү шарты белән билгеле бер срокка товар сату яки акча һәм материаль кыйммәтләрне процент алу исәбенә бурычка биреп тору. [*Мирзахан:*] *Эшебез яхшы, быел безгә Мәскәү фирмалары ун мең кредит бирде.* Т. Гыйззәт. [*Батырҗан:*] [*Колхозчылар*] *уңышны синең белән миңа карагандa бермә-бер артык алалар.* [*Яруллa:*] *--- Теләсә кайдан кредиткa машиналар китерепме?* Ф. Бурнаш.

2. Билгеле бер максат өчен сметада каралган сумма, акча средстволары. *Социалистик халык хуҗалыгы ихтыяҗларыннан чыгып, дәүләт кредит планнары билгели. Бу планнарда кредитның күләме, аның чыганаклары һәм юнәлеше күрсәтелә.* Политэкономия.

Кредит акчалары (билетлары) — кәгазь акчалар, матди кыйммәте булмаган, билгеле бер чор яки шартларда сәүдә һәм алмашу операциясендә түләү чарасы хезмәтен үти торган кәгазь билгеләр. [*Николай I заманында*] *электә чыгарылган кәгазь акчалар (кредит билетлары) көмеш белән сумга сум алмаштырылганнар.* СССР тарихы.

КРЕДИТОР *и.* Товар яки акчаны кредитка биреп торучы (кеше, учреждение, оешма, ил). *Кредиторлар килерләр, Малың кайда дип сорарлар, Кибетеңнән куарлар.* Ш. Мөхәммәдев.

КРЕ'ДО *и. кит.* Берәүнең дөньяга шәхси карашы, мәсләге, иҗатында, эшчәнлегендә тоткан юлы. *Фәнни кредо.* □ *Язучының иҗат кредосын аңлау өчен романнан бер эпизод китерү кызыклы булыр.* Р. Мостафин. *Күрәсез, Фатих* [*Хөсни*] *--- нинди кыюлык белән үзенең асыл кредосын ап-ачык әйтеп салган.* Ә. Еники.

КРЕ'ЙСЕР *и.* Тиз йөрешле, яхшы коралланган зур сугыш корабле. *Коминтерн куйган часовойлар, --- Постларыгызда уяу торыгыз! Безгә каршы чыккан крейсерларның Борынларын кире борыгыз.* Һ. Такташ. *Крейсерлар безнең әле дә постта.* Н. Баян.

КРЕ'КИНГ *и.* Авыр нефть продуктларыннан (мазут, табигый нефть) җиңелрәк продуктлар (бензин, газолин һ. б.) эшләп чыгару; нефтьне куу (процессы).

КРЕ'КИНГЛАУ *ф.* Нефть эшкәртү, нефтьне куу.

КРЕМ *и.* 1. *махс.* Май, каймак һәм шикәр кебек нәрсәләрне туглап эшләнгән куе измә сыман масса, чәй янына куела торган татлы ашамлыклар әзерләүдә кулланыла. *Пирожныйлар суынгач, өсләрен каймакмай кремы белән бизәргә.* Йорт эшләре.

2. Тиренең (аерата бит, кул) нәфислеген саклау өчен кулланыла торган косметик май. *Бизәнми, Кирәкми аңа Иннеге, кремнары; Чөгендер түгел, җиләктәй Бик матур иреннәре.* Г. Зәйнашева.

3. Күн аяк киемнәрен чистарта торган махсус май, буяу. *Камали да --- иске куныч таба, шундый ук табан сала, баш саба, үкчә утырта, крем белән каралта, хәтфә белән көзге кебек ялтырата да --- базарга юнәлә.* Г. Ибраһимов.

КРЕМАТО'РИЙ *и.* Мәетләрне яндыру миче. [*Дошманның*] *үлем арсеналында ачлык, газап, агу, газ, крематорий мичләре кебек „кораллары“ әле бетмәгән.* Н. Дәүли.

КРЕМА'ЦИЯ *и.* Мәетләрне махсус бинада, мичтә яндыру.

КРЕМА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Махсус мичтә мәет яндыру.

КРЕМЛАҮ *ф.* Биткә крем сөртү, крем ягу. || Күн аяк киемен крем белән майлау.

КРЕМЛЫ *с.* 1. Крем (1 мәгъ.) ягып әзерләнгән, крем белән бизәлгән. *Кремлы торт.*

2. Кремланган, крем белән майланган. *Кремлы итек.*

КРЕМЛЬ *и.* Россиянең борынгы зур шәһәрләрендә калкурак урынга төзелгән эчке крепость. *Әйе, Москвага бару, Кремльне, метроны, йортларны күрү үзе зур бәхет бит ул.* Р. Ишморат. *Киткән чакта Казан Кремле Магнит төсле тартты уемны.* М. Җәлил. || *күч.* Совет хөкүмәте мәгънәсендә (Мәскәү Кремле турында). *Җавап бирде миңа җитез ханым: Мин ашыгам ерак җиргә, Сабыйларның бәхет тулы таушын Кремльгә җиткерергә.* Ш. Маннур.

КРЕМНЕЗЁМ *и.* Кремнийның кислород белән кушылмасы, икеле окисе (кварц, ахак, тау хрустале, ком һ. б. хәлендә табыла һәм силикат промышленностенда кулланыла). *Кремнезем бик авыр эрүчән каты матдә.* Химия.

КРЕМНЕЗЕМЛЫ *с.* Составында кремнезем булган. *Кремнеземлы туфрак.*

КРЕ'МНИЙ *и.* Күпчелек тау токымнары составында шактый зур өлешне алып тора торган химик элемент. *Яр буйларындагы гади ком, нигездә, кремнийдан тора.* Гом. биология.

Кремнийның икеле окисе — *к.* кремнезем.

КРЕ'МНИЙЛЫ с. Составында кремний булган; комлы, комташлы.

КРЕМ-СО'ДА *и.* Салкын эчемлекнең бер төре; татлы су.

КРЕН *и. махс.* Самолет яки судноның хәрәкәт итү вакытында билгеле бер дәрәҗәдә янтаюы. *Крен ясап борылу.* □ *Уртаң парус кына әкрен искән җилгә киерелә, көймәне ярты крен хәлендә ярга алып бара.* А. Таһиров.

КРЕ'НДЕЛЬ *и.* Төче камырдан 0 яки 8 цифры рәвешендә пешерелгән камыр ашы. *Крендельләре майда гына пешкән, телгә тимәс борын әреп китәләр.* Д. Аппакова.

КРЕОЗОТ *и. хим.* Агач яки ташкүмерне куудан калган дегет сыман сасы матдә (техникада һәм медицинада кулланыла).

КРЕОЛ *и.* 1. Африкада һәм Латин Америкасында элек Европадан күчеп килгән кешеләр нәселеннән булган ак тәнле кеше.

2. Ата-анасы ике төрле расадан булган кеше (мәсәлән, португалияле белән индеец).

КРЕП *и.* Өсте кытыршы итеп тукылган юка йон яки ефәк тукыма. *Кырыйларына кара креп тоткан кайгылы кызыл байраклар мәйданга таба агылалар.* И. Гази.

КРЕП- Кайбер ефәк тукыма атамаларының беренче кисәге: **крепжоржет, крепмарокен, крепсатин** һ. б.

КРЕПДЕШИН *и.* Тыгыз туңылган юка ефәк тукыма. [*Мөнирәнең*] *өстендә бик әйбәт крепдешин күлмәк.* М. Хәсәнов. *Зәңгәр крепдешин күлмәген нинди килешле теккән.* Ф. Кәрим.

КРЕПОСТНИК *и. тар.* Реакционер, крепостной право тарафдары.

КРЕПОСТНИКЛЫК *и. к.* крепостнойлык. *Крепостниклык богаулары.*

КРЕПОСТНОЙ *с.* 1. Алпавытның крестьян шәхесенә, мөлкәтенә һәм хезмәтенә тулы хокукын тәэмин итә торган иҗтимагый стройга мөнәсәбәтле. *Крепостной бәйлелекне Ленин крепостной коллык дип атады.* Политэкономия.

2. Алпавыт милке саналган, алпавыт милкендә булган. *Баш күтәргән крепостной крестьяннарның юлбашчысы Пугачев күпмедер вакыт Бөгелмә тавында лагерь корып торган.* Г. Әпсәләмов. || *и. мәгъ.* Крепостной крестьян. *Булат крепостнойларны көрәшкә оештыра.* М. Җәлил.

Крепостной право — алпавытның үз биләмәсендәге крестьяннарның шәхесе, хезмәте һәм милке белән теләсә ничек эш итә алу хокукы. *Крепостной правоны бетерү.*

КРЕПОСТНОЙЛЫК *и.* Крепостной правога нигезләнгән җәмгыять. [*Г. Тукай*] *фольклорны феодаль крепостнойлык калдыкларына каршы көрәштә көчле коралларның берсе итеп алды.* Г. Нигъмәти. || *с. мәгъ.* Шундый җәмгыятькә һәм гомумән крепостной правога мөнәсәбәтле. *Крепостнойлык тәртипләре.*

КРЕ'ПОСТЬ *и.* Озак вакытлы оборона максаты белән һәр яктан да ныгытылган корылмалар системасы, ныгытма; кальга. *Хәзергә әле ул шау-шу таш койналы крепость эчендәге дворецка килеп җитми иде.* К. Нәҗми. || Гаебе аерата зур саналган (гадәттә политик) тоткыннарны ябу өчен махсус төрмә. — *Бер бунтка катнашканлык өчен яңадан крепостька ябылдым.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Үтәлӛчәк зур эш; яулап алыначак җиңү. *Алынмаслык крепостьлар юк безнең алда.* Ә. Исхак.

КРЕ'СЛО *и.* Артлы-култыксалы, гадәттә йомшак урындык. *Палас өстендә йомшак кәнәфи, ике кресло һәм өстенә кыйммәтле, бәйләнгән эскәтер[1] япкан түгәрәк өстәл.* Г. Коләхметов. *Гамактан ерак түгел, үлән өстенә селкенмәле кресло (качалка) чыгарып куелган.* Ф. Әмирхан. || Театрда тамашачылар өчен куелган урындыклар. *Һәммәсе дә үз алдына бертөрле эрелек белән ложаларда яисә алгы рәт креслоларда килбәтләнеп утыралар.* Ш. Камал. || *күч.* Урын, җитәкчелек посты, идарә итү эше. [*Гөлчирә Мирзаханга:*] *Шулай да, мин әйтәм, атаңның* [*волость старшинасының*] *креслосында озак утырасың. Варислыкны бик ныклап алгансың, ахры.* Т. Гыйззәт.

КРЕСТЬЯН *и.* Төп эше җир эшкәртү, иген игү, мал асрау булган авыл кешесе, игенче. *Аклар отряды авылга, гаскәргә ашатырга дип, крестьяннарның соңгы сыерларын алырга килде.* һ. Такташ. *Садри ярлы крестьян иде.* Г. Минский.

КРЕСТЬЯНЛЫК *и.* Крестьян булу; крестьян эше. [*Сәлимҗан:*] *Хәзер менә авылда.* [*Гөлнур:*] *Шулай итеп, крестьянлык итәсез?* Ф. Бурнаш.

КРЕСТЬЯНЧА *рәв.* Крестьян кебек, крестьянга хас булганча. *Моңа хәтле ул* [*Якуб*] *үзе дә крестьянча уйлаган булган шул: алырга да бүлешергә.* И. Гази. — *Минемчә, ул* [*Фрунзе*] *безнең шикелле буразнадан күтәрелгән кешедер. Нигә димсез? Җиргә бик нык басып тора, нәкъ крестьянча.* Г. Бәширов.

КРЕТИН *и.* Кретинизм белән авыручы.

КРЕТИНИЗМ *и. мед.* Калкансыман бизнең нормаль үсмәве сәбәпле була торган физик һәм акыл ягыннан зәгыйфьлек авыруы.

КРЕТОН *и.* Буялган җептән тыгыз итеп эшләнгән мамык тукыма, гадәттә, чехол, кап һ. б. ясау өчен кулланыла. *Кретон тышлы утыргыч.*

КРЕЩЕ'НИЕ: крещение суыклары *сөйл.* — январьның беренче яртысында була торган суык (христиан дине буенча 6 (19) январьда үткәрелә торган дини бәйрәм көненнән алынган). *Шәйхаттар бабай әйткән крещение суыклары җитә торгандыр, ахры.* Г. Гобәй.

КРИ'ЗИС *и.* 1. *филос.* Капиталистик илләрдә товарны чагыштырмача артык җитештерү һәм массаның сатып алу сәләте кимү аркасында барлыкка килә һәм периодик кабатланып тора торган, нәтиҗәдә производствоның кыскаруына, эшсезләр санының кискен артуына китерә торган күренеш. *Промышленность кризисы, эшсезлек эшчеләр хәрәкәтен туктатмады.* М. Җәлил. *Америкада да хәзер Зур кризис башланды, Эшелон-эшелон товар Кичә суга ташланды.* Н. Исәнбәт. || *күч.* Кыен хәл, җитмәүчелек һ. б. ш. сәбәпләрдән (эш) тукталу. *Заводларда кризис башланды: я чуен җитми, я тимер юк.* Х. Садрый.

2. Капиталистик илләрдә: халык массасының дәүләт власте политикасына каршы көрәшендә килеп чыккан кискенлек, политик кризис.

3. *мед.* Авыруның хәлен яхшырта яки начарайта торган кискен үзгәреш, авыруның хәле авырлашкан момент. *Кичә „үләм, үләм" дип ятkан кеше бүген танымаслык булган, алыштырып киткәннәрмени үзен. Димәк, кризис үткән.* Н. Дәүли.

КРИМИНАЛИСТ *и.* Криминалистика белгече.— *Сез Италия криминалисты Ломброзо теориясе ягындамы?* А. Гыйләҗев.

КРИМИНАЛИ'СТИК *с.* Криминалистикага мөнәсәбәтле. *Криминалистик тикшеренүләр.*

КРИМИНАЛИ'СТИКА *и.* Хокук фәненең җинаятьне тикшерү методларын өйрәнә торган бүлеге.

КРИМИНО'ЛОГ *и.* Криминология белгече.

КРИМИНОЛО'ГИЯ *и.* Җинаятьне социаль күренеш булу ягыннан өйрәнү фәне.

КРИПТОГРА'ММА *и.* Криптографик язу, криптографиягә нигезләнеп язылган язу. [*Бу*] *криптограмма сез күренекле шагыйрь Һади Такташның пионерлар өчен язган маршыннан өзек укырсыз.* Сов. мәк.

КРИПТОГРА'ФИЯ *и. кит.* Аерым кешеләр өчен исәпләнгән яки уйлап төшенү өчен билгеләнгән шартлы, яшерен язу.

КРИСТАЛЛ *и.* 1. Күпкырлык рәвешендәге каты җисем. *Алмазның кристаллар челтәре.* || *күч.* Саф, ихлас күңелле булу символы. — *Котлыйм, дбүзәр Гиреевич, Коммунистлар партиясенә нәкъ менә сезнең кебек кристалл шикелле саф кешеләр кирәк.* Г. Әпсәләмов. [*Тукайда*] *ташып ятkан йөрәк моңы, кристаллча саф самимилек бар.* Г. Нигъмәти.

2. *күч.* Ныгыган, чыныккан, көчле. *Авыр корбан бирде эшче сыйныф, Күпме кристалл ирләр югалды.* Г. Афзал.

КРИСТАЛЛАШТЫРУ *ф. махс.* Кристалларга әверелдерү, кристалл хәленә китерү.

КРИСТАЛЛАШУ *ф.* 1. Җисемнәрдә газ яки сыеклык халәтеннән каты кристаллар барлыкка килү процессы. *Тозларның кристаллашуы.*

2. *күч.* Билгеле бер ныклы формага әйләнү; формалашу. *Латифның гомере буена кристаллашкан дөньяга карашы, холкы һәм тышкы үзенчәлеге үзгәрмәячәк.* А. Расих.

3. *күч.* Чыныгу, каты, нык, җиңелмәс булып әверелү. *Кристаллашкан Ленин партиясе Алып бара безне җиңүгә.* М. Крыймов. *Гомер-гомер кайнап кристаллашкан Явызлыкка каршы — гаделлек.* Г. Афзал.

КРИСТАЛЛИЗА'ТОР *и. махс.* Химик кушылмаларны кристаллаштыру, кристаллга әверелдерү приборы. *Суыткычлар, кристаллизаторлар һәм центрифугалар аша үтеп, тиешенчә чистартылган --- бу матдәне цех ел тәүлегенә әллә ничә мең тонна чыгара.* Э. Касыймов.

КРИСТА'ЛЛИК *с.* Кристалл хәлендәге, кристалл рәвешендәге. *Каты җисемнәр ике төрле булалар — кристаллик һәм аморф матдәләр.* Физика.

КРИСТАЛЛО'ГРАФ *и.* Кристаллография белгече.

КРИСТАЛЛОГРА'ФИЯ *и.* Кристаллның төзелеше һәм формалары турындагы фән. *Николай Иванович --- өстәлгә кристаллография буенча кулланманы да куйды.* Ж. Тәрҗеманов. *Югары математика, физика, химия --- кристаллография — барысы да табигатьтә үз урыныңны табу, дөньяда адашмау, көрәшү, җиңү өчен.* Э. Баянов.

КРИСТАЛЛЫ *с.* Кристаллардан торган. *Кристаллы сланецлар.*

КРИСТАЛЛЫК *с.* Кристалл булу хәле. *Кристаллык торышы.*

КРИТЕ'РИЙ *и.* Берәр нәрсәгә бәя бирү, аны теге я бу төркемгә кертү өчен нигез булып торган билге. *Хикәянең сыйфат дәрәҗәсен билгели торган критерийларыбыз төгәл микән?* М. Әмир. || Караш. [*Мамайкин*] *бөтенләе белән начальствога ышанган һәм аңа тапшырылган. Аның үз критерие юк.* Ә. Фәйзи.

КРИ'ТИК I *с.* Кискен үзгәрешкә китерә торган, кискен үзгәреш башлангычы булган. *Критик нокта.* || Иң кыен, куркыныч. *Критик момент. Критик хәл.*

Критик температура *физ.* — җисемдә сыек халәт белән пар халәте арасында аерма бетү, ягъни сыек хәлдән пар хәленә күчү температурасы.

КРИ'ТИК II: **критик реализм** *филол.* — әдәбиятта һәм сәнгатьтә тормышны, чынбарлыкны тәнкыйть аша дөрес чагылдыруны төп метод итеп алган әдәби агым. [*Г. Камал*] *критик реализм юлы белән иске черек тормышны --- фаш итте.* М. Гали.

КРОВАТЬ *и. к.* карават. *Ана, мамык юрганы белән төренеп, авыр-авыр сулап, кроватьта ята идә.* А. Шамов. *Кровать җыйнак һәм матур күренә иде.* Ф. Әмирхан.

КРОКЕТ *и.* Агач чүкечләр белән шарларны кечкенә капкаларга кертеп уйнала торган уен. *Балалар су коенырга бару, көймәдә йөрү, я крокет уйнау турында сүз куешалар.* Г. Әпсәләмов.

КРОКОДИЛ *и.* Тропик илләрдә яши торган, калын каты тиреле сөйрәлүче эре су хайваны.

◇ **Крокодил күз яше** — чын күңелдән булмаган, ясалма, хәйләле, риялы үкенү. *Надежда Николаевнаның күңелендә шик кузгалды: бу дүхәдиев бер-бер нәрсә хәйләләмиме? Аның күз яше крокодил күз яше түгелме?* Г. Әпсәләмов.

КРОН *и.* Кайбер Көнбатыш Европа илләрендә акча берәмлеге. *Малай үзенә дә „хезмәт" өчен ике крон көмеш алдан алырга онытмый.* А. Таһиров.

КРОНГЛАС *и. тех.* Оптик приборлар өчен махсус пыяла.

КРОНШТЕЙН *и.* Нәрсәне дә булса (балкон, шүрлек һ. б.) стенага, баганага һ. б. га перпендикуляр беркетү өчен эшләнгән таяныч, җайл анма.

КРОСС *и. спорт.* Ярыш (йөгереп, чаңгыда, велосипедта, мотоциклда һ. б. да узышу). *Һәрбер ярыш безнең мәктәп даны, Җиңүчеләр булыйк кросста.* Ж. Тәрҗеманов.

КРОССВОРД *и.* Шакмаклардан торган фигурага хәрефләр язып, аерым сүзләр китереп чыгару — табышмак-уен. *Кроссворд чишү.*

КРУ'ЖКА *и.* Стакан формасындагы тоткалы савыт (гадәттә 200 гр. — 1 кг. сыешлы була). [*Табынга Каюм*] *үзенең калай кружкасы белән генә килеп утырды.* Ә. Фәйзи.

КРУПЧА'ТКА *и. сөйл.* Ак онның иң яхшы сорты.

КРУ'ШНИК *и. сөйл. к.* крючник. *Иделгә беренче пароход төшү белән, Тимери --- Астрахань ягына крушник булып китте.* Г. Бәширов.

КРУ'ШНИКЛЫК *и. сөйл.* Крушник булу. [*Шәрәфи карт*] *Волганың түбән як пристаньнарында йөк ташучы крушниклыктан башлап --- күп эшләүче мастер ярдәмчесе булу дәрәҗәсенә җиткән.* Ш. Камал.

КРЫЖО'ВНИК *и.* 1. Әчкелтем-татлы җимеш бирә торган чәнечкеле куак үсемлек. *Крыжовникны --- текә битләүләргә һич тә утыртырга ярамый.* Җиләк-җимеш...

2. Шул үсемлекнең җимеше. [*Мәликәнең*] *өлгереп җитмәгән крыжовник төсле ямь-яшел күзләре кинәт ничектер оп-оҗлы булып ялкынланып китте.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Шул җимештән эшләнгән. *Крыжовник вареньесы.*

КРЫ'НКА *и.* Тар авызлы сөт чүлмәге. *Иртәгесен әлеге теге сөтле крынка тагын килде.* Ф. Хөсни.

КРЮ'ЧНИК *и. сөйл.* Грузчик, аркага асылган махсус җайланма белән пароход яки баржалардан йөк ташучы. — *Заманында, Мәкәрҗәдә крючник булып йөргән чакларда, Мәрфуга әбиеңне хәйран калдырырлык бүләкләр алып кайта идем.* С. Сабиров.

КРЮШОН *и.* 1. Исерткеч эчемлек: җимештән ясалган аракының ром, ликер яки коньяк белән кушылмасы.

2. Татлы салкын эчемлек, җимеш суы.

КСЁНДЗ *и.* Поляклларда католик рухани. — *Байның аның миллионеры да, бояры да, ксендзы да, шулар рәтеннән побы да бергә каералар.* А. Таһиров.

КСЕНОН *и.* Химик элемент: электротехникада кулланыла торган инерт газларның берсе.

КСЕРОФОРМ *и.* Ярага яки пешкән урынга сибү өчен кулланыла торган сары порошок (висмут һәм бром кушылмасыннан тора).

КСИЛО'ГРАФ *и.* Ксилография белгече; агачка чокып рәсем төшерү остасы.

КСИЛОГРА'ФИК *с.* Ксилографиягә мөнәсәбәтле.

КСИЛОГРА'ФИЯ *и.* Агачка чокып рәсем төшерү сәнгате. *Фәнни басмалардагы гарәп текстлары ксилография ысулы белән эшләнгән.* Каз. утл. || Агачка чокып ясалган рәсем яки хәрефләр төшермәсе.

КСИЛОФОН *и. муз.* Агач пластинкаларга агач таякчыклар белән сугып уйный торган музыка коралы.

КУ 1. *с. иск.* Коры, корыган, кипкән (агач, үлән). *Ку үләнгә үрт салу.* Әйтем. || Эче буш, коры; шүре сыман. *Бура торып калган бернәрсәсез, Нәкъ җилеген алган ку сөяк.* М. Гафури.

2. *и.* Черек каен төпләрендә үсә торган каты гөмбәнең киптерелгәне, кипкән мәшкә (ут кабызу өчен кулланыла). [*Карт*] *аркасына ку, чакма вә башка сәфәр әсбаплары салынган биштәрне асты.* Шура. *Чакмадан атылып чыккан очкыннардан әлеге ку пыскып яна башлады.* М. Госманов.

КУА *с. к.* коба. *Куа сыерны сатып, кышка әзрәк өс-башны рәтләмәкче булып торабыз.* Ф. Хөсни.

КУАК *и.* Төптән үк диярлек ботакларга тармакланган тәбәнәгрәк агач үсемлек. *Чия куаклары, алмагачлар Чәчәкләргә күмелеп утыра.* Ә. Ерикәй. *Чем-кара җимешләрен елтыратып, нигәдер гаҗәпләнгәндәй, карлыган куаклары карап тора.* Г. Бәширов.

КУАКЛАНУ *ф.* Ботак яки тармак җибәрү, тармаклану.

КУАКЛЫ *с.* Куактан торган, куак, вак агачлары булган. *Ә куаклы урман читендә Машиналар тынып калганнар.* Ш. Маннур.

КУАКЛЫК *и.* Куаклар үсә торган урын, әрәмә. *Үләннәр, Илсөярнең ак каеннары, су читендәге талтирәкләре, будка тирәсендәге куаклыклар — бөтенесе дә саргая башлаганнар иде.* Г. Гобәй. *Алкин чыга: — Сездә куаклыклар Алган камап кырлар арасын.* Ш. Мөдәррис.

КУАЛАУ *ф.* 1. Куып бару, нинди дә булса юнәлештә барырга мәҗбүр итү. *Мужик озын тал чыбык илә казларны сөреп куалап --- бара иде.* Г. Тукай. *Озын Себер юлы... Тау битеннән атын атлатып, Соры чикмәннәрне җилгә каршы Куалыйлар мылтык шартлатып.* М. Җәлил. || Әйдәп бару, кызурак атларга мәҗбүр итү (җигелгән яки атланган атны һ. б.). — *Әйдә, Мифтахетдин, атларны куала, энем.* Ш. Камал.

2. Көчләп кая да булса җибәрү, кая да булса барырга мәҗбүр итү. [*Патша хөкүмәте халыкны талады*], *Суярга алып барган куйлар кебек, Көтү-көтү сугышка --- куалады.* Ш. Мөхәммәдев. || Куып җибәрү, (эштән) куып чыгару. *Тузан кадәр гаеп тапсалар да, Куалыйлар эштән үзеңне.* М. Крыймов.

3. Куу, үз янынан китәргә мәҗбүр итү. *Мин аны куалап чыгардым да, ишегемне бикләп, шәмне сүндереп, бүлмәнең бер башыннан икенче башына йөри башладым.* Г. Ибраһимов.

4. Тоту өчен артыннан чабу, йөгерү. [*Кара сакаллысы*] *кешеләргә: — Куала! Тот! Җибәрмә, — дип акыра иде.* Г. Бәширов.

5. *күч. к.* куу 4. *Без сәгатькә 70 чакрым куалый торган немец поезды белән алга тәгәрәдек.* Г. Гали.

КУАНДЫРГЫЧ *с.* Шатлык, куану хисе бирә торган. *Куандыргыч хәбәр.*

КУАНДЫРУ *ф. к.* шатландыру. *Андрейның ата фашистка каршы ялгыздан-ялгыз батырларча көрәшүе һәм җиңүе Бакыйны бик нык куандырды.* Г. Әпсәләмов. — *Дүрт кешене бердән куандыру да, көндерү дә синең кулыңда.* М. Фәйзи.

КУАНУ *ф.* 1. Шатлану, сөену, шатлык, канәгатьлек хис итү. *Һәм куанам минем яшьлек көчем кирәк булуына илемә!* Ш. Маннур. *Куану һәм пошыну, канәгатьләнү һәм борчылу белән тулы була безнең һәр көнебез.* Ә. Еники. || *и. мәгъ.* Куаныч, шатлык. *Куанудан шунда еладым, Шомырт ботакларын кочаклап.* Ф. Кәрим.

2. Дәртләнү (казларның аталану чорында була торган хәле). *Ашамаган каз куанмый.* Мәкаль.

КУАНЫЧ *и.* Шатлык, сөенеч. *Чыннан да бит кайчак шулай Бик кечкенә булышу да Дустың өчен көтелмәгән Зур куаныч булып чыга.* З. Мансур. *Сөйгәненең куанычын Уртаклаша Булат та.* М. Җәлил.

КУАНЫЧЛЫ *с.* Шатлыклы, сөенечле. [*Хәйдәр*] *бүген иртәдән бирле үзендә куанычлы бер күтәренкелек, бер дулкынлану сизә иде.* Г. Бәширов. || Шатланган, куанган. *Чәй катында елмая куанычлы әткәсе.* Г. Тукай.

КУАНЫЧЛЫК *и.* Куаныч, шатлык. *Җирдә яшәүнең әйтеп бетерә алмаслык куанычлыгы бар.* С. Рафиков.

КУАНЫШУ *ф.* 1. Бергәләп куану, шатланышу. *Һәм йөрербез куанышып бергә, Тургайларны тыңлап яланда.* Ш. Маннур. *Кызлар, куанышып, Нургали абыйларын озатып калдылар.* Ә. Еники.

2. Дәртләнү, дәртләнешү (казларның аталану чорындагы хәле). *Ишек алдында казлар куаныша.*

КУАС *и. к.* квас. [*Әхмәт:*] *Миңа куас кына китерсен.* Г. Камал.

КУБ I *и.* 1. *мат.* Һәр ягы квадрат булган алты кырлы геометрик фигура.

2. Күләм үлчәү берәмлеге: **кубсантиметр** — иңе, буе һәм биеклеге 1 см.; **кубметр** — иңе, буе һәм биеклеге 1 метр һ. б. || *сөйл.* Иңе, буе һәм биеклеге бер метр булган күләм үлчәү берәмлеге; кубометр. [*Бетон салу*] *стенага хәтле --- Алтыбызга туксан куб була.* Ш. Маннур.

3. *мат.* Нинди дә булса санның үз-үзенә ике мәртәбә кабатланган тапкырчыгышы, санның яки хәрефле билгеләмәнең өченче дәрәҗәсе: a^2b^3 (*а* квадрат, *b* куб). *Санны кубка күтәрү.* || Тамырның өченче дәрәҗә билгесе: $\sqrt[3]{}$ — куб тамыр.

КУБ II *и.* Сыеклыкны кайнату яки парга әйләндерү өчен хезмәт итә торган күп сыйдырышлы, капкачлы зур савыт яки казан. *Мәктәп ишек алдында --- зур ашханә. Анда һәрвакыт куб кайнап тора, теләгән чагында чәйне әҙ бир.* З. Бәширн. [*Солдатлардан*] *берәү: Ә монда кайнар су табып буламы? — дип сорады. — Юк, куб кайнатучы әшчене үтерделәр.* Ш. Усманов.

КУБАЛАК I *и.* Умарта түбәсе астына куелган такта.

КУБАЛАК II *с.* Яргаланып купкан, купкаланган. *Кубалак борынлы.*

КУБАЛАКЛАНУ *ф.* Яргаланып, вак-вак кисәкләр булып кубу, яргаланып кубу. [*Габделхәй*] *кояшта кубалакланып беткән борынын әледән-әле шыштырдатып тарткалап куя.* Г. Ахунов. *Коры тире бик нәфис, юка була, еш кына кубалаклана.* Азат хатын.

КУ'БАЛЫ *и.* Куба иле кешесе. *Кичә кубалылар безне үзләренә чакырды.* Р. Мостафин.

КУБА'НКА *и.* 1. Бәрән тиресеннән тегелгән яссы түбәле, тирән эчле колаксыз бүрек. [*Хазбулатның*] *өстендә --- бөрмә билле черкеска, башында иң яхшы бөдрә бәрән тиресеннән тегелгән кубанка.* Р. Ильяс. | *с. мәгъ.* [*Хафизның*] *башында кубанка бүрек, өстендә кожан иде.* Г. Галиев.

2. Бодайның бер сорты. *Кубанка бодае.*

КУБАРУ *ф.* 1. Ябышкан, ник береккән нәрсәне аерып алу, җирлегеннән аеру. *Кригер* [*патша рәсеме астына ябыштырган кәгазьне*] *кубарып ала да укый.* Т. Гыйззәт. *Давыл кайсыдыр өйнеңме, сарайныңмы түбәсен кубарып ташлады.* Г. Әпсәләмов.

2. Күтәрү, чыгару (тузан, давыл һ. б.). *Акларның җәяүлеләре, атлылары тузан кубарып монда таба чабалар.* Г. Бәширов. || *күч.* Тавыш, гауга, ызгыш һ. б. чыгару, башлап җибәрү турында. *Патый әби тавыш кубарырга сәбәпче булды.* А. Шамов.

3. Кузгату (уй, хисләрне). *Кондаков егет күңеленда нинди уйлар кубарганын сизенде.* А. Гыйләҗев. || *күч.* (Эш) кузгату, нәрсәне дә булса (зур бер эшне) булдыру. *Менә әйтер күк: „Юк, булмый Пычагым да кубарып...“.* С. Хәким.

4. *күч. жарг.* Каеру, күп итеп алу. *„Шәһәргә даныңны чыгарам“ дип куркытып, егетеңнән --- шактый гына кубарган идем.* Г. Камал.

КУБАРЧЫКЛАНУ *ф. к.* кубалаклану. *Батырғали агайның борыны өшеп, тиресе кубарчыкланып кутырлаудан чыкмый торган иде.* Ш. Мөхәммәдев.

КУБАРЫЛУ *ф.* 1. *Төш, юн. к.* кубару. *Һавадагы төтен әчендә агач кисәкләре, кубарылган җир уентылары тузынып очып йөри.* Г. Кашшаф. || Куптарылу, аерылу. *Суккан саен сугылучының тәненнән чәчрәп кан һәм ит кубарылып чыга иде.* М. Гали. || Күтәрелү. *Кубарыла давыл, җил бәрә.* Ә. Ерикәй.

2. *дини.* Үлгән кешеләрнең кыямәт көнендә, имештер, яңадан терелүе. — *Калганы теге дөньяда, жаным. Ансын инде анда карарбыз... Яңадан кубарылгач.* Н. Исәнбәт.

КУБАТУ'РА *и.* Нәрсәнең дә булса кубметрлар белән үлчәнә торган күләме. — *Дни, шушы фатирыбыз кай җире белән начар? Кубатурасы да әйбәт, бакчасы да бар.* Ә. Фәйзи.

КУБИЗМ *и.* Сынлы сәнгатьтә реаль чынбарлыктагы әйберләрне геометрик фигуралар белән ясауны яклый торган буржуаз формалистик агым. *Художниклар арасында кубизм дигән агым килеп чыккан. Кешеләрнең гәүдәсен, битен шакмакларга бүлеп ясаудан гыйбарәт икән кубизм дигәннәре.* И. Гази.

КУ'БИК *и.* 1. Куб формасындагы зур булмаган фигура, шакмак (балалар уенчыгы). *Ул кирпечләр нәкъ кубиклар кебек.* А. Алиш. | *күч. Абыйлар кубиклардан биек-биек йортлар салалар.* А. Гыйләҗев.

2. Кубсантиметр (сыеклык үлчәү берәмлеге). *„Бер кубик камфара“, — дигән сүзләр ишетелеп кала миңа.* Ә. Айдар.

3. 1943 елга кадәр Совет армиясендә урта комсоставның хәрби звание билгесе. *Өч кубиклы* [*командир*] *һәм кузовтан сикереп төшкән берничә кызылармеец* [*яралы апаны*] *сакланып кына күтәреп алып, өенә, җыештырылмаган кроватена кертеп салдылар.* Г. Гобәй.

КУБОВОЙ *и.* Куб тора торган бүлмә, су кайнату бүлмәсе.

КУ'БОК *и.* Спорт ярышларында җиңүчегә приз итеп бирелә торган, кыйммәтле материалдан эшләнгән савыт — ваза.

КУБОМЕТР *и.* Иңе, буе, биеклеге берәр метр булган күләм үлчәү берәмлеге; кубметр. *Ике кубометр утын.* □ *Һәркайсы берәр кубометрлы ул бадьялардан --- сыек бетон килеп төшә.* Ш. Маннур.

КУ'БРИК *и.* Суднонын аскы палубасы. *Багажларыбызны урнаштырганнан соң, үзебезгә ял итәр өчен кубриктан урын бирде.* С. Сабиров.

КУБУ *ф.* 1. Ябышкан, береккән урыныннан аерылу, аерылып төшү. *Түбә калайлары урыннарыннан кубарга теләп шалтырыйлар.* Ф. Әмирхан. [*Итекнең*] *берсенең балтыры ертыла төшкән, икенчесенең олтаны кубып киткән.* Ш. Камал. || Кубалаклану һәм вакланып коелу. *Утта булган балчык кире купмас, Эштә булган тимер тутыкмас.* М. Җәлил. *Илсөяр акшары кубып, пычранып беткән өч катлы йорт өстендәге --- вывескаиы укыды.* Г. Гобәй.

2. *сөйл.* Кузгалу, тору, күтәрелү (утырган яки яткан урыннан). *Нургали урыныннан кубып, яман кызып сөйләргә тотынды.* Ә. Еники. *Газиз урыныннан кубып йөренә.* Ф. Әмирхан. || Кинәт кузгалу, хәрәкәт итә башлау, туктап, басып торган урыннан китү. *Берәр кеше аткан саен, өер белән кубып, мишень тактасы янына йөгерештеләр.* И. Гази.

3. Башлану, чыгу, күтәрелү (көчле җил, буран, давыл турында). *Бервакыт буран купты.* Г. Ибраһимов. *Давыл кубар, тиздән, көчле давыл.* А. Алиш. || *күч.* Күтәрелү, кинәт башланып китү (тавыш, шау-шу, гауга һ. б.). *Президиум сайлый башлагач, тавыш яңадан купты.* А. Шамов. *Кайдадыр пароход кычкыртты. Якын-тирәдә яман шау-шу купты.* Г. Бәширов. || Сугыш, фетнә һ. б. ш. башлану турында. *Юк, купмасын иде тагын сугыш...* С. Хәким. *Күп тә узмады, купты сәнәкчеләр фетнәсе.* Г. Ахунов.

КУБЫЗ *и.* 1. Дуга сыман бөгелгән тимер чыбыкка юка гына тел беркетелеп, авызга куеп чиртеп уйный торган кечкенә музыка коралы. *Малайлар да чираттлашып аның кураен, --- я кубызын алып, авызга куеп чиртеп карыйлар.* М. Гали.

2. *к.* **кобыс.** *Шаулап аккан чишмәнең моң, тәңкә тавышын тыңланып, Нечкә кылдан чиртәм әкрен, кыл кубызны, моңланып.* Н. Исәнбәт.

Кубыз тарту — кубыз уйнау. *Кубыз тартсаң, көй була, бүрәнә тартсаң, өй була.* Мәкаль.

◇ **Кубызына бию** — кемнең дә булса теләге, кушуы, өндәвенә сукырларча ияреп эш итү, ихтыярсыз буйсыну. — *Инде утызга якынлашкан, авылның авторитетлары арасында йөргән кешегә яшь кенә хатын кубызына бию килешәме?* Э. Касыймов.

КУБЫЗЧЫ *и.* **1.** Кубыз чиртү остасы, кубыз уйнаучы.

2. *күч. сөйл.* Кемнең дә булса кубызына биюче, аның әйтүенә карап эш итүче кеше. *Татар буржуазиясенең күптәнге кубызчысы, реакцион „мөселман иттифакы"н оештыручы бу кеше* [*Муса Бигиев*] *Октябрь тантанасыннан соң бөтен зәһәрен пролетариат диктатурасына юнәлтте.* К. Фасеев.

КУБЫК *с.* Кубалакланган, яргаланып, кубып-кубып торган. *Кубык борынлы шул малайның бездән алдарак мәйданга ыргылуы белән һич килешәсе килми.* Р. Төхфәтуллин.

КУВАЛДА *и.* Зур чүкеч. *Заклепка вакытында чүкеч сугасың, чүкечне кувалда алыштыра.* Ф. Хөсни. *Ногман - - - Идәндә яткан алты килограммлы авыр кувалданы алып Нурмыйга кизәнде.* Р. Ильяс.

КУВШИН *и.* Тар авызлы (гадәттә тоткалы) чүлмәк. *Якуб бер кисәк пирог, бер кувшин сөт алып яр буена ашарга утырды.* И. Гази.

КУГА *и. бот.* Сазлыклы урыннарда, су буйларында үсеп, тәлгәшле чәчәк ата торган кыяк үлән.

КУГУАР *и. зоол.* Төньяк һәм Көньяк Америкада яши торган зур кыргый мәче.

КУГЫН *и.* **1.** Качкан кешене тоту максаты белән әзәрлекләп куып бару.

2. Куып, әзәрлекләп килүчеләр, куучылар төркеме. [*Ш. Бабич*], *артыннан кугын куып бик озак йөгергән кеше төсле, шабыр тиргә баткан, тәмам әлсәрәгән иде.* С. Әдһәмова. *Бер кемне дә тоталмады Волостьның кугыны да.* С. Баттал.

КУДЫРГЫЧ *и. тех.* Кудыру, торба буйлап икенче бер урынга җибәрү өчен насос сыман махсус җайланма, агрегат. *Нефть кудыргыч. Су кудыргыч.*

КУДЫРТУ *ф.* **1.** *к.* кудыру. — *Мәсьәләне идарәгә куячакмын, кудыртачакмын.* Г. Ибраһимов. *Батыргали агай бу запасной солдатларны хәтта балконнан кудыртмакчы да булган иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Кудыргыч машина ярдәмендә сыеклык яки газны торбалар аша бер урыннан икенче урынга күчерү, агызу. — *Коралларны хәзерләгез. Хәзер кудыртабашлыйбыз, — диде Садыйков.* Р. Ильяс. *Тымытыктан көчле насослар белән бу якка* [*Бөгелмә—Карабашка*] *Ык суын кудырталар.* Г. Бәширов.

КУДЫРУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* куу. — [*Һәдия*] *ара бутап йөри икән, Нургали абыйдан үзебез сорап, фермадан кудырабыз.* Ә. Еники.

2. Куу (7 мәгъ) юлы белән эшкәртү, кирәкле матдә ясау. *Нефть кудыру.* □ *Хафизулла кунакларга дип тәкә суйдырды, самогон кудырды.* Г. Минский.

КУЕ *с.* **1.** Бер-берсенә бик якын, тыгыз, еш урнашкан; *киресе:* сирәк. *Кыз - - - җитез хәрәкәтләр белән куе таллар арасына кереп югалды.* М. Әмир. || Еш һәм тыгыз урнашкан, кабарып, күпереп торган, калын (мәс., чәч, керфек, үлән һ. б.). [*Хәят*] *озын куе вә үз-үзләреннән күперенеп тора торган, кара ефәк көлтәсе шикелле чәчләрен тараганда, Лиза дача хәлләрен сөйли торды.* Ф. Әмирхан.

2. Нәрсә дә булса салып, кушып куертылган (сыекча, измә); *киресе:* сыек. [*Иванов:*] *Дәе, тиз генә куе балчык сыекчасы белән сыларга.* А. Әхмәт.

3. Тыгыз, яктылык үткәрми торган (газ сыман әйберләр турында). *Ферма алачыгының морҗасыннан ишелеп-ишелеп куе төтен чыга.* Г. Нигъмәти. *Куе томаннар адаштырырга гына торалар.* А. Алиш.

4. Төс билгесе: төп төснең саф үзе генә, яки караңгырак, кара-кучкылрак булуы; *киресе:* сыек, ачык. *Хәзер* [*бодай кыры*] *куе яшел төскә кереп бара.* Г. Бәширов. *Ерактагы куе зәңгәрлектән Ак болытлар инде күренә.* Ш. Маннур.

◇ **Куе су** — малларга эчерү өчен он болгатып эзерләнгән туклыклы сыекча, ашлы су. *Яратам да соң шул йонлач Сарбайны. Мин аны гел үзем генә тәрбиялим. Аңа куе су, шулпа бирәм.* Г. Лотфи. **Куе сөт** — саума сөт, каймагын аерып алмаган сөт; *киресе*: сыек сөт, зәңгәр сөт. *Фән болай дип әйтә: сөтле сыер үстерәсең килсә, бозауга яшь чагында мөмкин хәтле күп итеп куе сөт эчерт, ди.* Ә. Еники. **Куе чәй** — чәен күп салып пешерелгән чәй. [*Мәрьямбикә*], *зур кисәк лимон салып, иренә дә, үзенә дә куе чәй ясады.* Г. Ибраһимов.

КУЕЛАТУ *ф. сөйл.* Куерту, баету. *Өндәү рәвешендә китерелгән сүзләр, сорау җөмләләр - - - Туфан шигырьләренең декламациячелек төсен куелата төшәләр.* Г. Нигъмәти.

КУЕЛМА *с.* Куелган; алып, куеп йөртергә мөмкин булган, даими беркетелмәгән. *Куелма тешләр. Тәрәзәнең куелма өлгесе.*

КУЕЛМАЛЫ *с. к.* куелма.

КУЕЛЫК *и.* **1.** Куе булу. *Ул кап-кара чәчләреңнең озынлыгы һәм куелыгы!* Г. Тукай. *Утыртуның куелыгы бәрәңгесенең сортына, бәрәңгеләрнең эрелегенә, туфракның уңдырышына һ. б. шартларга бәйләнгән.* Җиләк-жимеш...

2. Ешлык, урманның ерып йөри алмаслык куе урыны. *Атын җитәкләп, куелык буйлап, Бара яшь юлчы, зур уйлар уйлап.* З. Мансур. *Нәфисә, кулларын алъяпкыч күкрәгенә яшереп, урман куелыгына караган килеш, җырының агышы уңаена салмак кына башын чайкый.* Г. Бәширов.

КУЕЛЫШ *и.* Нәрсәнең дә булса куелу дәрәҗәсе, сыйфаты, тәртибе, торышы. *Штейгер килеп - - - терәүләрнең куелышларын, казылган балчыкларның сыйфатларын күзеннән үткәрде.* М. Гафури. *Полиграфия мәктәбенә барудан теләк — аны карау һәм аның куелышы белән танышу, өйрәнү.* Ғ. Гали. *„Качкын" операсының куелышы — татар совет культурасы тарихында зур вакыйга.* М. Җәлил.

КУЕН *и.* **1.** *к.* кочак 1. *Бик туңам бит, әтием, куеныңда җылытса идең.* М. Җәлил. || Күкрәк. [*Марат*], *уенны онытып, башын әнисенең куенына төртә.* Г. Гобәй. || Кием белән күкрәк яки шул турыдагы тышкы кием белән эчке кием арасы. *Куенга бер кисәк икмәк белән берничә бәрәңгене кыстырып, тагын чыгып чабабыз.* Г. Ибраһимов. *Миңнурый, куеныннан чиккән яулык чыгарып, оялып кына Газинургa сузды.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Яратышу, сөешү; ятакта бергә булу. — *Сөнгать сөйләнеп йөрсен әле, мин монда* [*Маһруй*] *куенында рәхәтләним.* М. Фәйзи.

3. *күч. шигъ. к.* кочак 7. *Кыр куйнында, Шаушуларга күмелеп, Комсомоллар җыелыш үткәрде.* М. Крыймов. *Агыйделнең буенда, Карурманның куйнында Яшәгән минем бабам.* Ш. Маннур. || Җирнең эче, җир асты. *Җәмиләне кара кабергә — мәрхәмәтле җир куенына илтеп күмделәр.* М. Гафури.

◇ **Куен дәфтәре** — иң кирәкле мәгълүмат, эшләнәчәк эш, фикерләрне теркәп бару өчен янда йөртелә торган хәтер дәфтәре, блокнот. *Нәфисә бу сорауга куанып, зәңгәрсу кыска бишмәтенең эчке кесәсеннән коңгырт тышлы кечерәк кенә куен дәфтәрен чыгарды.*

Г. Бәширов. **Куен кесә(се)** — киемнең эчке ягына күкрәк турына салынган кесә. *Мин аларны, үз сөйгәнемнең хатлары кебек итеп, куен кесәмдә саклап йөртәм.* И. Гази. **Куен сәгате** — кесә сәгате. [*Сабира*] *күлмәк кесәсеннән куен сәгате чыгара.* М. Җәлил. **Куенына керү** — егет, кыз, кияү, кәләш сүзләре янында: өйләнешеп, беренче төнне үткәрү. *Кыз бүген аулак өйгә бармады, аның урынына егет куенына зөфафка керде.* Г. Ибраһимов.

КУЕНТЫК *и.* Куенга (1 мәгъ.) охшаш урын. *Яфраклар куентыкларында үскән бүлбечекләр дә җиргә коелалар.* Ботаника.

КУЕРТКЫЧ *и. к.* конденсатор.

КУЕРТУ *ф.* 1. Сыеклыкны берәр нәрсә өстәп яки башка юл белән куерак хәлгә китерү, куе массага әйләндерү, куеландыру. *Измәне куертү.* || Болганчык хәлгә китерү (суны), болганчыкландыру.

2. *күч.* Көчәйтү, арттыру (тәэсир көчен һ. б.). *Җиһангир бу полиция катнаштыру моментын тагы куертып җибәрде.* Г. Ибраһимов. *Дәүләтьяров белән Курманаев, үзләрен шушы авылдан сайлатырга уйлап, Сараланда агитацияне бик куерттылар.* И. Гази. || Зурга җибәрү, катлауландыру; җитдиләштереп җибәрү. *Минһаҗетдин, хатынының сүзе кая барганлыгын бик яхшы сизенеп, мәсьәләне куертмас өчен коры гына:* — *Кысса ни булган...* — *диде.* К. Тинчурин.

КУЕРУ *ф.* 1. Куе, еш үсү, куелык, ешлык хасил итү (агач, куаклар турында). [*Зөфәр*] *бакчаның карт булуын, бик куерып киткәнлеген, гомумән, карау җитмәгәнлеген сизмичә калмады.* Ә. Еники. || Калынаю, тыгыз һәм күпереп торган хәлгә җитеп үсү (чәч, үлән һ. б. турында). *Бүреләрнең, төлкеләрнең йоннары куерды.* Г. Әпсәләмов. [*Айсылуның*] *өске иренендәге сизелер-сизелмәс кенә кара төкләре тагын да куера төшкән иде.* Г. Бәширов.

2. Куе масса хәленә керү, ката башлау (сыеклык турында). *Суыкта нефть куерса, шуннан соң инде ул труба эчендә акмый башлый.* А. Әхмәт. || Болгану, болганчык хәлгә керү (су). *„Парча“ суларың да куермыйча, уймакланып ишелеп аксыннар.* Һ. Такташ.

3. Куе (3 мәгъ), үтә күренмәслек хәлгә җитү, тагы да тыгызлану. *Басу ягыннан күренгән болытлар кургашланып куера башладылар.* Г. Минский. *Кичке эңгер-меңгер куерып җиткән иде инде.* Г. Гобәй.

4. *күч.* Һава составының начарлануы, кислородка ярлыланулы. — *Сестра, монда һава бик куерып китте әле. Дллә - - - идәнне сөрттереп аласыңмы?* А. Шамов.

5. *күч.* Көчәю (сүз, әңгәмә һ. б. турында). *Аерым артистлар турында сүз куерып китте.* М. Әмир. *Туй көнендә таралган начар-пычрак гайбәт куерып җәелә - - - башлады.* Г. Ибраһимов. || Зурга китү, җитди төс алу (берәр эш яки вакыйга). *Тарихи вакыйгалар ул кышны куерып китте.* Ә. Еники.

6. *күч.* Йокыга ою, йокы халәтенә керә башлау. *Сәмигулла абзый үзе йоклап китәр алдыннан, куерып кына ята торган карчыгын уятып: - - - Чәйне ничә кадак алсам ярар икән?* — *дип сорады.* Ф. Әмирхан.

КУЕРЫК 1. *с.* Болганчык; болганган, пычрак. *Куерык суның акканы яхшы.* Мәкаль. || *и. мәгъ.* Куе масса. *Җәрәхәттән агып чыккан кан куерык хасил итә.* Анатомия.

2. *и.* Спирт, шикәр, сыра һ. б. эшләгәндә производство калдыгы; *русчасы*: барда.

КУЗ *и. диал.* Утлы күмер. *Кешеләр озын таяклар белән ялкын төбендәге утлы күмер, кайнар кузны таратып ташладылар.* М. Госманов.

КУЗАК *и.* Кайбер үсемлек орлыкларының (борчак, фасоль, сәрви һ. б.) озынча тар кабыгы, тартмачыгы. *Сыбызгыны мин сәрви агачы кузагыннан ясыйм.* А. Әхмәт. [*Кеше*] *берничә сабак борчак йолкып алды да кузакларын чүпли башлады.* Г. Гобәй.

Кузак(лы) борыч — орлыгы грушага охшаш тартмачыкка (кузакка) урнашкан, пасленчалар семьялыгыннан бер еллык үсемлек; *к.* кызыл борыч.

КУЗАКЛАНУ *ф.* Кузаклар барлыкка килү. *Борчагы нәрсә бит! Инде бөтенләй кузакланып беткән* — *сырга кебек, сабакны сыгып утыралар.* Г. Ибраһимов.

КУЗАКЛЫ *с.* Орлыклары кузакка урнашкан. *Кузаклы үсемлекләр.*

КУЗАКЧА *и.* Борчак кузакларына охшаш кечкенә кузак, ул аерым бүлекчәләрдән тора, һәр бүлектә бер орлык була. *Торма, кәбестә, шеббуйның кузакчалары тышкы күренешләре белән кузакка охшыйлар.* Ботаника.

КУЗАЛАК: кузалак арба — ике тәгәрмәчле ат арбасы. *Мокыт абый кузалак арба җигеп бабасына килгән.* Мәзәк.

КУЗГАЛАК *и.* Ашарга ярый торган озынча ачы яфраклы күпьеллык үсемлек. *Хәлим көн саен яшь кычыткан, балтырган, кузгалак җыеп кайта.* И. Гази. *Ярлылыкта яр табылса, кузгалак та аш булыр.* Мәкаль.

Кузгалак кислотасы — техниканың төрле өлкәләрендә: ситсы материалын ману, химик чистарту, синтетик буяулар ясау һ. б. да кулланыла торган төссез кристалл формасындагы органик кушылма.

КУЗГАЛАКЛЫК *и.* Кузгалак күп үскән урын.

КУЗГАЛУ *ф.* 1. Тик тору халәтеннән чыгу, селкенү, хәрәкәт итә башлау; кыймылдау. [*Командир*] *каты яраланган, хәле авыр, кузгала да алмый.* Ә. Айдар. *Аның инде кул һәм аяклары сизми, кузгалмый, салкын һәм авыр ташлар шикелле түбән тарталар.* Ш. Камал.

2. Утырган яки яткан урыннан тору яки торып китү.—*Юк-юк, чәй эчерми җибәрү юк,—дип, Габдулланы кузгалган җиреннән кире утырта.* Ә. Фәйзи. || Тик тору хәленнән динамик хәрәкәткә күчү, алга таба хәрәкәт итә башлау. *Кучер сикереп утыруга, атлар кузгалды.* Г. Ибраһимов. *Поезд әле кузгала гына башлаган.* А. Шамов. || Кая да булса юнәлү, юлга чыгу. —*Ярый, Газинур,—диде ул, —шулай алайса, иртәгә таң белән кузгалабыз.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Көрәшкә күтәрелү, ирек даулап көрәшкә чыгу; баш күтәрү. *Кузгалдык без туган илне фашистлардан сакларга.* Ә. Ерикәй. *Алпавытка каршы кузгалабыз бит.* И. Гази.

4. Йокыдан тору, төнге тынлыктан соң хәрәкәт итә башлау, эшкә тотыну. *Ул кояш белән бергә кузгала, Көрәген ала, җиңел сызгана.* М. Җәлил. *Сызылып аткан таң соңында һәммә җәнвар кузгала.* М. Гафури.

5. *күч.* Ачу, нәфрәт, мәхәббәт һ. б. ш. хис яки уй, фикер туу, барлыкка килү турында. *Аның йөрәгенә берәмләп өелеп килгән кайгылар кузгалып, давылланып киткән шикелле булды.* А. Шамов. *Картны артыннан килеп кочаклаган кешегә Мәрьямнең күңеленда ачу кузгалды.* Ш. Камал. || Авыруның кинәт көчәеп китүе, тынып торудан өянәк хәленә күчүе. —*Бая сез Камилә белән кычкырышкан тавышка йөрәгем кузгалып китте.* Г. Камал. —*Бүселемнең кизүе кузгалды.* Т. Гыйззәт.

6. *күч.* Күтәрелү, кинәт башланып, көчәеп китү (җил, давыл, буран һ. б. турында). *Кичкә таба җил кузгалды.* Г. Минский. *Менә бөтен дөньяны һәлак итәм дип көчле давыл кузгала.* Г. Коләхметов. || Ташу, елгаларда боз китә башлау турында. *Боз кузгалыр, диләр, тиз көннән.* Г. Хуҗиев. || Талаш, сүз, шау-шу һ. б. турында. *Газетада хәбәр чыгып, шау-шу кузгалгач, ул* [*Мөбарәкша*] *бөтенләй хат язудан*

туктады. К. Нәҗми. || Көн тәртибенә куелу, төп мәсьәлә итеп күтәрелү. *„Чулпан" колхозының ун еллык бәйрәмен үткәрү мәсьәләсе үзеннән-үзе кузгалды.* Г. Галиев.

КУЗГАЛЫШ *и.* 1. Кузгалу, урыннан тору, хәрәкәтләнү эше. *Кәримулла карт та, нәрсәгәдер урынынан торырга теләп, омтылып куйды. Ләкин ул тормады. Яңадан урынына утырды һәм, бу урынсыз кузгалышын акларга теләгәндәй, кара постау туның төймәләрен башта кызу гына чиште, аннары ашыкмый гына яңадан төймәләде.* А. Шамов. || Хәрәкәт. *Үзеңне иҗтимагый бер бөтеннең кечкенә кисәге, алга булган кузгалыш механизмының кирәкле винты итеп сизенү - - - - болар яңаны төзү чорының үзенә генә хас булган сыйфатлары.* Г. Нигъмәти.

2. Баш күтәрү; восстание. *Шәкерт кузгалышы.* *Петроградта менә-менә эшчеләр кузгалышы булырга тора.* Ш. Камал.

КУЗГАЛЫШУ *ф.* Кузгалу, хәрәкәт итә башлау (күп кеше турында). *Без икебез дә урыннарыбыздан кузгалыштык та, үзебез дә белмичә, бер-беребезгә каршы килештек.* Ф. Әмирхан.

КУЗГАТКЫЧ *с.* Кузгатып җибәрә торган; урыннан кузгата, хәрәкәткә китерә яки бирәр эш яисә хәлне башлап җибәрә торган. [*Тикшерүче*] *берничә яктан кузгаткыч сорау биреп, картның сүз тегермәнен әйләндереп җибәрде.* Г. Ибраһимов.

КУЗГАТУ *ф.* 1. Хәрәкәтләндерү, кыймылдату, тик тору хәленнән чыгару. *Чәч кузгатып, Җай искән Таңгы җилем, исән бул!* Дәрдмәнд. *Уң аягым бик каты сызлый, башым үтереп чатный, аягымны кузгатырга телим, кузгата алмыйм.* Ә. Айдар.

2. Утырган яки яткан урыныннан күтәрү, торгызу. *Әлеге карчык: „- - - кузгатмыйча гына карагыз", —дип, авыруга кагылырга да бирми.* Г. Кутуй. *Ялгызлыктан газапланган Илсөяр тәрәзә төбендә кояш нурларында гамьсез мырлап яткан песине кереп кузгатты.* Г. Гобәй. || Хәрәкәт иттерә, йөртә башлау. *—Рәхмәт! —диде Айрат, кузгатып атын, —Җиңеп чыгармын, шул булсын аңтым.* З. Мансур. *Машинаны кузгатыр куәтле пар.* М. Гафури. || Күчерү, бер урыннан икенче урынга куя яки торышын үзгәртү. [*Карт*] *урындыкларны дөбердәтеп кузгатып, кызын сөяргә дә бармакчы булган иде,* [*карчык*] *тотып алды.* А. Шамов.

3. Уяту, йокыдан торгызу. *Барактагы егетләрне дә Исак гадәттәгедән иртәрәк кузгатты.* Ш. Камал. || Эшкә күтәрү, оештыру. *Теге вакытта Айсылу кузгатып җибәргән әби-бабайлар „Чулпан"ның хәтсез эшен киметтеләр.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Берәр хис, рухи халәт хасил итү. *Чулпының чылтырап йөрүе егетнең күңелен кузгата, мәхәббәтен уята, ди торганнар иде.* М. Фәйзи. *Бу кичәләр хәтта җырлый белми торган, гомумән музыкадан ерак кешеләрнең дә дәртен кузгатты.* Ә. Фәйзи. || Чирне көчәйтүгә, кинәт авырта башлауга сәбәпче булу. *—Я тагын өянәгемне кузгатырсың.* Р. Ишморат.

5. *күч.* Күтәрү, тикшерүгә кую (мәсьәләне), берәр нәрсә турында сөйли башлау. [*Нуретдин*] *терлекләрнең нәселләрен яхшырту мәсьәләсен кузгатты.* Ә. Еники. *—Ходай йортында — мәчеттә кузгатканчы, чыккач, урамда кузгатырга иде ул дөнья сүзләрен.* М. Гали. || Суд тикшерүенә бирү турында. *Миңнулланың үлүе белән Шәмгун карт өстеннән кузгатылган суд әше дә туктатылды.* А. Шамов.

6. *күч.* Берәр зур эш башлау, эшкә тотыну турында. *Бик мәшәкатьле чагым, —диде* [*Нурый карт*]. *—Менә хәзер өй кузгатырга торам, җир-урман алдым.* Г. Ибраһимов.

КУЗГАУ *ф. сөйл. к.* кузгату. *Җилме кузгый корыган ботакны?* Н. Исәнбәт. *Их, шушы яз, бөтен күңелләрне дәртләндереп, кузгап җибәрә.* Ш. Маннур.

КУЗЛА *и.* 1. Арба яки чананың алгы өлешендә ат тотучы (кучер) утыру өчен махсус ясалган урыны. *Хәлим кара лаклы зур тарантас кузласына утырган.* Г. Гобәй.

2. Аяклары бер-берсенә аркылы сугылган бүрәнә формасындагы стан (утын кискәндә кулланыла). [*Газинур*] *биек кузлаларга аркылы салынган бүрәнә өстенә сикереп менде.* Г. Әпсәләмов. *Ишек алдында ике малайның кузлага салып озын пычкы белән әрдәнә тураганнарын күрдем.* Г. Галиев. || *спорт.* Төрле гимнастик күнегүләр өчен ясалган махсус снаряд; *русчасы:* козел.

3. Берничә мылтыкны штыгы белән югары каратып бер-берсенә сөяп куйган пирамида.

Кузла җөе—уң ягы кузла аягы кебек (Х ка охшаш аркылы-торкылы җепләрдән торган), сул ягы атлатып җөйләнгән ике параллель сызыктан гыйбарәт булган чигү җөе, күбесенчә, сыпылмаган ертыкны типчү яки әдепне беркетү (әдепләү) өчен кулланыла. *Киемнәрнең кырыйларын (итәген, кесәләрен) теккәндә җөй калып, тупас булырлык булса, кузла җөен кулланалар.* Һөнәрленең кулы алтын.

КУЗЛУТ *и. бот.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык чүп үләне; *русчасы:* жабрей. *Бу алан хәзер сарут, кузлут, алабута һәм саргайган кыяк үләннәр белән күмелеп калган.* А. Гыйләҗев.

КУЗНА *и.* Сарык, кәҗә, ат, сыер кебек хайваннарда ашык сөяге, бәкәл сөяге (балаларның җәй көне ачык һавадагы уенында кулланыла). *Шагыйрь кайсы вакытта идарәханәгә кесәсенә кузна тутырып килә.* Ф. Әмирхан. *Алгы якта* [*Фәрит*] *кузналар санап маташа иде.* Ш. Камал. || Шул сөяк белән уйнала торган уен. [*Сәхәү*] *кузна уйнаганда килеп чыкса, - - - кузналарыбызны тибеп очыра - - - иде.* М. Әмир.

КУЗНАЛЫ *и.* Кузна уены. *Ду килеп, тиргәшә-талаша, кузналы уйныйбыз.* Ш. Маннур.

КУЗОВ *и.* Йөк машинасының кешеләр утырту һәм йөк төяү әрҗәсе. *МТС директоры Зәйнуллин, шофер кабинасына утырмыйча, кунаклар янына кузовка урнашты.* Г. Минский.

КУЗЫ I *и.* Астрахань чикләвеге; *русчасы:* грецкие орехи. [*Базар рәтендә*] *зур-зур бәйләмнәрдә тимгел-тимгел яшел бананнар, кузылар, өрекләр, шәфталу, бадәм һәм пестәләр.* Р. Мостафин. *Битенең яралары ямалу урынына чигәсе кузы шикелле кабарып чыгарга өлгергән.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КУЗЫ II *и.* Курчак сүрүе, тышчасы, пәрәвезе; *русчасы:* кокон. *—Ефәк кортларын һәм аларның кузыларын - - - сарайга җыеп китерегез.* З. Бәширн. *Кортлар куак төбендә яки үләндә ефәк пәрәвез кузыларда курчакланалар. Июль-август айларында кузылардан күбәләкләр чыга.* Җиләк-җимеш...

КУЗЫ(Й) *и.* Бәрән, сарык бәтие. [*Әбелхарис:*] *Куй, Әбугали. Куян елны өч сумнан кузы да сатып алмыйсың.* Ә. Фәйзи. *Кыз кочмаган ирнең җаны тыныч, кузгалак ашамаган кузый тыныч.* Мәкаль. *Дөя җуйса колынын, Иртә-көндез иңридер, Куй югалтса кузыйсын, Иртә-көндез мөгридер.* М. Җәлил.

КУЙ *и. к.* сарык. *Сары бишмәтле итче, кулына пычак алып, бер куй суя башлады.* Г. Тукай.

КУЙЧЫ *и. иск.* Куй көтүче, өлкән чабан. [*Арысланбайның Карлыгач-Сылуны урлап кайтуын*] *башта ялчы хатын белде. Ул, куркып, хәйран калып, куйчыга сөйләде.* Г. Ибраһимов.

КУЙЧЫЛЫК *и. иск.* Сарык асраучылык.

КУК *с.* Кукрайган, масайган, күкрәген киергән. *Сез мине борынын һавага чөеп, бүксәне киереп атлаучы кук егет итеп күз алдыгызга китерә күрмәгез тагын.* Р. Төхфәтуллин.

◇ **Кук итеп йөрү**—кукраю, күкрәк киереп йөрү. *Ачык ишектән өйгә, биш-алтылап тавык ияртеп, кук итеп әтәч килеп кергән.* Мәзәк.

КУКРАЮ *ф.* Күкрәк киереп, „мин кем“ дип йөрү: масаю, борын күтәрү. *Әмиржанга погоннар белән озак кукраеп йөрергә, Садыйк хаҗига, Әмиржан өстенә карап, озак шатланырга туры килмәде.* Ш. Камал. *„Мин кем!“ дигән сыман, бер әтәч кукраеп утыра.* И. Гази.

КУКУРУЗ *и.* 1. Берөйлеләр семьялыгыннан орлыклары чәкән формасында булган, юан озын сабаклы, кыяк яфраклы берьеллык үлән үсемлек. *Саматов җитлеген килгән бодай басуларыннан, бүйга күтәрелгән кукуруздан, мең төрле чәчәкләр белән бизәлгән болыннардан күзен ала алмыйча карап тора.* Г. Минский. [*с. мәгъ. Кукуруз басуы.*

2. Шул үсемлекнең орлыгы, бөртеге. || *с. мәгъ.* Кукуруз бөртегеннән әзерләнгән. *Кукуруз крахмалы.* □ *Ул бик кызыктыргыч сап-сары төстә һәм бик тәмледер сыман тоелган кукуруз буткасы иде.* Ш. Маннур.

КУКУРУЗЧЫ *и.* Кукуруз үстерүче, кукуруз үстерү остасы.

КУКУРУЗЧЫЛЫК *и.* Кукуруз үстерү, кукуруз игү эше. *Кукурузчылыкны үстерү.*

КУКШИН *и. сөйл. к.* кувшин. *Әбинең бер кулында кукшины, икенче кулында, култык астында, кечкенә генә төен кисәге.* Г. Гали.

КУЛ I *и.* 1. Кеше гәүдәсенең ике яныннан чыгып торган пар әгъза. *Аягы бар, кулы бар, бара торган юлы бар.* Әйтем. || Шул әгъзаның беләзектән түбәнге өлеше, чугы. *Кул кулны юа, ике кул битне юа.* Мәкаль. *Кулга тотыйм синең изге кулны—Күп эш белән талган кулыңны.* М. Гафури.

2. *күч.* Берәр эшне, шөгыльне башкарган көч, корал, чара; билгеле бер эштә, шөгыльдә, эшчәнлектә катнашлык. *Гыйлаҗи совет ягыннан көрәшеп, аклар кулы белән үтерелә.* Г. Нигъмәти. *Революция каһәрле кул белән бастырылганнан соң, мәдрәсә тагын иске юлына кайтты.* М. Гафури. || Берәр эшнең уйланылган, гөман ителгән башкаручысы турында. *Инде менә бүген шундый әйбәт, чуклы башлы сөлге югалган икән, Хәтирә кулы булмыйча, кемнең кулы булсын?* Г. Минский. || Берәр эшне эшләүченең яки шуны башлаучының эш барышына яки эш нәтиҗәсенә йогынтысы (кара ышану) турында. *Кулы җиңел. Кулы авыр.* □ *„Кулы тәмле“ дип, күрше-күлән дә тавыкны Мөстәкыйм-нән сүйдыра иде.* М. Әмир.

3. *күч.* Як, тараф, юнәлеш (уң яки сул сүзләре белән генә кулланыла). *Сул кул якта аксыл бодай һәм солы кырлары дулкынланып торган төсле күренә иделәр.* Ш. Камал. *Уң кулда амбарлар, урталыкта кечкенә күпер, сул кулда берничә агач.* Ф. Бурнаш.

4. Почерк, кемнең дә булса язу рәвеше; имза. *Бер кәгазь кисәгенә адәм танымаслык начар кул белән Фәхри яза.* Г. Ибраһимов. *Конвертны ертып, имзасына күз салдым; гәрчә: „Дустыгыз Батыргали Шалканов“ дип кул куйган булса да, кулы безнең Батыргали агайның кулына бик охшамаган иде.* Ш. Мөхәммәдев. || Әйбер эшләнешендә индивидуаль алым яки осталык чалымы. *—Моны таныйсызмы? —Нигә танымаска? Үземнең эш! Үземнең кул!* Г. Ибраһимов.

5. *күч. кыек килеш форм.* Хакимлек, власть; биләүче-лек. *Петроградта Совет большевиклар кулына күчкән.* И. Гази. *Без кол идек бай кулында. Бога у-зынҗырлар муенда.* Г. Камал. *Коткардылар безнең гвардеецлар Зур авылны немец кулыннан.* Ш. Маннур. || Ихтыяр, карамак. *Балаларыгыз кеше кулында үссәләр, сезгә әйләнеп тә карамаслар.* Г. Тукай. *Ярларыгыз безнең кулда—Милициягә киңәш ит.* Җыр.

6. *күч.* Иялек, хуҗа булу. *Крепость коллыгы заманында крестьяннар кулында булган җирләр азатлык вакытында кисеп калынып, крестьяннар җирсезләнделәр.* Г. Нигъмәти.

7. *күч. у.-вак. килешендә.* Кулга алынган булу, тоткынлыкта булу турында. *Сашкасы да, кулак Латыйбы да кулда хәзер. Аларның судлары булачак.* А. Расих.

8. *күч. сөйл. кыек килеш форм.* Берәмләп сатучылар даирәсе (зур сәүдә системасына каршы куелып әйтелә). *Кулдан алу.* □ *— Стансага баручы булса, шырпы апкайтырга кушасың бар, кызым. Анда кулдан табып була, диләр.* Р. Төхфәтуллин. *Кая, Хәким, чемоданыңны миңа сат әле, син башкасын алырсың; тагын кулда табылыр әле.* Г. Газиз.

9. *күч.* Нарасый баланы беләкләргә утыртып (яткырып) йөртү турында. *Кулны ярату. Кулдан төшү.* □ *Сабый әнисе аша Гөлсем апага үрелде. Кулга килгәч, бер дә ятсынмыйча, аның колак алкалары, ак беретындагы фил брошкасы белән уйнап торды.* Г. Гобәй.

10. *күч.* Хатын-кызның тормышка чыгарга ризалыгы. *— Алар бар да хан кызының кулын өмет иткән, бәхетләрен сынарга чыккан морза егетләре.* Н. Исәнбәт.

11. *рәв. мәгъ.* **кулдан.** Һич кичектермәстән һәм турыдан-туры (түләү, расписка бирү һ. б. ш. турында). *Кулдан акча бирү.* □ [*Шәкертләр*] *гафу үтенсеннәр, моннан соң идарәнең куйган тәртибе буенча яшәргә кулдан язу бирсеннәр!* Г. Ибраһимов.

12. *рәв. мәг.* **кулдан, кул белән.** Борынгы примитив кораллар белән яки кул көче ярдәмендә генә (машина белән эшләүгә каршы куелып әйтелә). *Кул белән тегү. Кулдан бәйләнгән оек.* □ *Хәзер ирген эшен бер дә кул белән эшләмиләр инде, чәчү дә, уру да, сугу да, суыру да — һәммәсе машина белән.* М. Гали. || Ташка басмыйча, каләм-карандаш белән генә язып. *Идел һәм Кама буе татарларында китап басу һөнәре барлыкка килгәнче --- кулдан күчерелгән язма китаплар йөргәнлеге билгеле.* И. Рәмиев.

Кул арбасы — кул белән тартып йөртә торган кечкенә йөк арбасы (гадәттә ике көпчәкле була). *Муллагали белән Мансур --- урманнан кул арбасы белән корыган ботаклар да алып кайттылар.* А. Расих. **Кул аркасы (сырты)** — кулның учка тискәре ягы. *Галәү бабай, торып, кул аркасы белән күзен уды.* Г. Гобәй. *Сабир абзый яшьләнгән күзләрен кул сырты белән сөртеп алды.* Ә. Еники. **Кул багажы** — кулга тотып кына йөртелә торган җиңел багаж. *Хәерттин --- килүче-китүчеләрнең кул багажларын ташыштыргалап йөри башлаган иде.* М. Гали. **Кул гранатасы** — кул белән ыргытыла торган граната. *Бәлагә каршы, ичмаса, кул гранаталарыбыз да юк.* А. Шамов. **Кул йөзе** — уч һәм бармаклар. *Кул йөзе чаклы (хәтле).* □ *Нәҗип, кул йөзенә пычак кайраган шикелле итеп, кулны кулга ышкып куйды.* Г. Гобәй. **Кул катогы** — кул көче белән тәгәрәтеп йөртелә торган каток. *Кулына кечкенә кул катогы алып, бая машина каерган эзне тигезләүче [кеше] — Галимә.* М. Хәсәнов. **Кул пулеметы** — күтәреп йөртелә торган җиңел пулемет. *Лида, яраланган кызылармеецны алмаштырып, кул пулеметыннан атты.* Г. Әпсәләмов. **Кул пычкысы** — бер кул белән генә эшләтелә торган кечкенә пычкы. **Кул станы** — кул көче белән эшләтелә торган стан. *„Ткацкий“ дип аталган бу катта постау суга торган, агачтан ясалган кул станнары бер-бер артлы тезелеп киткән.* М. Гали. **Кул сугышы** — атышусыз кара-каршы сугыш. [*Солдатларны*] *кул сугышы*

белергә, кыскасы, разведчик өчен нәрсә кирәк булса, шуларның барысын да өйрәнергә мәҗбүр иттеләр. Г. Әпсәләмов. **Кул сәгате** — кулга тагып йөртелә торган сәгать. *Уң яктагы күршем уянды да мендәр астыннан кул сәгате алып карады.* Ә. Айдар. **Кул тегермәне** — гадәттә кул белән әйләндерелә торган кечкенә тегермән. *Зиннур кечкенә - - - кул тегермәне белән нидер тарттыра.* А. Расих. **Кул тырмасы** — кул белән эшләтелә торган тырма. *Соң без моны кул тырмалары белән йомшартып карасак ничек булыр икән?* Г. Бәширов. **Кул фонаре** — кулда тотып йөртелә торган фонарь. *Ишек ачылып, ишектән кул фонаре тоткан бер офицер, дүрт солдат керделәр.* Һ. Такташ. **Кул чугы** — кулның беләзектән түбәнге өлеше — уч һәм бармаклар. **Кул яссуы** — 1) яссы һәм туры хәлдәге кул (кул очы). *Фәхри, гадәтенчә, кул яссуы белән югарыдан түбәнгә һаваны кисте.* Г. Ибраһимов; 2) уч киңлеге; уч киңлеге кадәр озынлык үлчәме. *Гариф белән Мортаза абый, бер-берсеннән бер генә кул яссуы калышып, мәйданга керделәр.* М. Гали.

◇ **Кул алу** — күрешү, саубуллашу яки дуслык билгесе итеп сузылган кулны кабул итеп кысу. *Шушы булыр безнең иптәшләрчә Күрешеп кул алу.* М. Җәлил. **Кул арасына (астына) керү** — йорт тотуда һәм эштә олыларга ярдәм итә башлау (үсмер балалар турында). *Сәүдәгәрнең углы булса: „Тизрәк тире-ярыга тотындырырга кирәк, кул арасына керсен", — ди.* Г. Тукай. *„Дни берүзе җитешә алмый шул. Сажидә апа аның кул астына керә алмый, аягы юк".* Ә. Фәйзи. **Кул астына алу** — 1) үз җаваплылыгыңа алу (башкару, үтәү өчен). *Уракчылар кул асларына алган кишәрлекләрен уралар.* М. Гали; 2) хакимлекне, җитәкчелекне яки берәр кешене, группаны һ. б. туласынча үз карамагына алу. *Булдыклы килен бианасын да кул астына алыр, биатасын да биетер.* Мәкаль. **Кул астына туры килү** — ашыккан яки кызган, ярсыган чагында тотарлык урында булу. *Мәликә берничә көн тузынып йөрде; кул астына туры килгән нәрсәләрне ачуланып ыргытып бәрде.* А. Шамов. **Кул астында** — 1) җитәкчелегендә, карамагында. *Әминә кул астында сестра булып эшләргә тиешле уңган кыз Наилә чәй дә кайнатып куйган.* Г. Минский. *Мидхәт үзенең кул астындагыларга боерык бирде.* Г. Гобәй; 2) якында, тиз генә алырлык урында. *Улакта чылбырга бәйләнгән агач чиләкнең кул астында булуы ифрат җайлы.* С. Рафиков. *Сиңа боларның барчасын эшләү бик җиңел, чөнки синең кул астыңда гына урман бар.* Г. Тукай. **Кул баглау** — кулларның терсәктән түбәнге өлешен күкрәк өстендә бер-берсенә чалыштырып, бер кул чугы белән икенче кулның юан беләген тотарлык итеп (яки тотып) тору — хезмәткә хәзерлек, тайярлык билгесе. *Шул сәгатьтә кырык агачның кырыгы да, бер кыяфәттәге адәм сурәтенә кереп, һәрберсе аягүрә калкып, кул баглап, әбелхарисның каршысына бастылар.* К. Насыйри. **Кул бару (бармау), кул күтәрелү (күтәрелмәү)** — берәр эшкә, начар яки күңел теләмәгән эшне эшли алу, алмау турында. *Үзләре шундый яхшы күңелле кешеләр, ә хайван суярга куллары бара.* Ә. Еники. *Ул көннәрдә урманнардан утын, бүрәнә ташырга крестьяннарның куллары бармады.* Х. Кәрим. *Теле күтәрелгәннең (яман эшкә) кулы да күтәрелә.* Мәкаль. *Шулай да мин аңа тырнак белән дә чиертә алмадым. Кулым күтәрелмәде.* Ф. Хөсни. **Кул белән алып ташлагандай** — авыру, авырту-газаплар тиз генә һәм бөтенләйгә тәмамлану турында. *Мин, вәҗдан газабының кул белән алып ташлагандай киңәт югалуына бик нык шатланып, иркен суладым.* А. Шамов. **Кул бирү** — 1) күрешү, саубуллашу, килешү яки дуслык билгесе итеп кешегә кулны сузу. *Димәк, син риза, алайса, бир кулыңны.* Г. Ибраһимов; 2) ярдәм итү. *[Надан кеше] егылганнарга кул бирмәс, батып барганга җеп [бау] сузмас.* Г. Тукай; 3) атаклы ишан белән вакыт-вакыт күрешеп, аның күрсәтмәләрен һәм фатихасын алу. *Бу мулла - - - Күнтәй авылының бер суфые белән Зәйнулла хәзрәткә кул биреп кайтырга бара.* М. Гафури. **Кул калу (калмау), кору (корымау)** — берәр эшне эшләгәннән кулга (гомумән сәламәтлеккә) зыян килмәгәнне белдергәндә кулланыла. *Кулалмашка кул талмас, эшләгәннән кул калмас.* Мәкаль. — *Кайда әйтсәләр дә бар. Аннан аягың калмас, кулың корымас.* С. Рафиков. **Кул карату** — кул сызыкларын багучыдан бактырып күрәзәләтү. *Кызганычка каршы, бүгенге көндә дә чегәннәрдән кул каратучылар очрый әле.* Соц. Тат. **Кул кулга йокмау** — бик җитез һәм кызу эшләү. *[Ибрай] инде эшкә күнә башлаган: кулларын кулга йокмый.* Г. Гобәй. *Кыймылдагыз, ут уйнатыгыз — кулыгыз кулга йокмасын.* Г. Бәширов. **Кул кушыру** — 1) кулларыңны (бармак араларына бармакларны кертеп) бер-берсенә тоттыру — хөрмәт белән тыңлау билгесе. *Аның [байның] бу сүзләрен башын иеп, кул кушырып тыңлый иде ул.* М. Гафури; 2) бернәрсә дә эшләмичә (чарасын күрмичә), битараф булып тору турында. — *Ләкин, — диде Якуб, — аклар бетәчәк икән дип, кул кушырып утырырга ярамый, Шәрифҗан!* И. Гази. **Кул кую** — 1) документ, хат яки башка берәр истәлекле язманың, картинаның һ. б. мәгънәсе өчен җаваплылык, шәһитлек яки ризалык билгесе итеп исем-фамилиянне язу. *Әнвәр азакка: „Беренче класс укучысы Әнвәр Тимербулатов" дип кул куйды.* Э. Касыймов; 2) раслау, ризалык, канәгатьлек белдерү. *Менә бусын — җыр дисәң дә ярый, Кул куямын менә бусына.* Ш. Маннур. — *Алайса, син инженер кебегрәк кеше икәнсең. Шәп, шәп, бусына кул куям.* Г. Галиев. **Кул кызу** — эш белән мавыгу, эшкә дәртләнеп китү; берәр эшне эшлисе килеп тору. *Бу оста - - - әйткән эшне ялтыратып эшләп куя, бер кулы кызгач, әйтмәгәнен үзе күреп тә эшли иде.* Ф. Хөсни. **Кул кыска (кыскарак)** — нинди дә булса эшне эшләргә ирек булмау, рөхсәт ителмәү, көч җитмәү турында. [Рөстәм:] *Я, егетләр, авылны бик кысмыйсызмы?* [*Госманов:*] *Кысар идек тә, кул кыскарак. Бик кысарга ирек бирмиләр.* Һ. Такташ. *Кесәсе сайның кулы кыска.* Мәкаль. **Кулыңны кыска тоту** — кыйнаусугудан тыелу (тыю) турында. *Әлбәттә, кызларны дхмәдидән кыйнатмаска. - - - Дхмәдигә кулын кыскарак тотарга кирәк.* Ә. Бикчәнтәев. **Кул кысу** — күрешү, саубуллашу, дуслашу яки тәбрикләү билгесе итеп кешенең кул чугын учлап кысу. [*Кайтып төшкәч*] *Кайсы коча, кайсы кулны кыса, Чәчәк суза кайсы кулыма.* Ә. Исхак. *Бригадир зур дәрт белән карт-ларның кулларын кысты.* М. Җәлил. **Кул кычыту** — берәр нәрсә эшләп ташларга яки берәрсен кыйнарга ашкынып, ярсып тору. *Гәрәй, йодрыкларын тәйнәп, Суфияга таба бара башлаган иде, Минһаҗ аның кулыннан тотты:— Кулың кычытса, кычытканга чактыр.* Г. Мөхәммәтшин. **Кул көче (хезмәте)** — физик хезмәт. *Минем әнием - - - кул көче белән эшләп гомер итүче.* Һ. Такташ. **Кул күтәрү** — 1) дини йола буенча: дога укыганда кулларны уч ягы белән биткә якын тоту. *Менә карчыклар, хәерле юл теләп, кул да күтәрделәр.* Г. Бәширов; 2) сугарга хәзерләнү, кизәнү; сугу. *Артта калган бер аңсызы Кул күтәргән хатынына.* Ш. Галиев; 3) җәмәгать урыннарында сөйләргә, җавап бирергә һ. б. теләк белдерү; 4) уң кулны баштан югарырак күтәрү юлы белән тавыш бирү, берәр карарга һ. б. ризалык белдерү. *Минем тәкъдимгә егермеләп кеше кул күтәрде.* Ш. Камал. — *Раифов дхмәтне классның стена газетасына хурлап язарга дип кул күтәрдек.* Г. Мөхәммәтшин; 5) бирелү, каршылык күр-

сәтмәү билгесе итеп ике кулны да баштан югары күтәрү. *Ул [солдат], куркып дошманы алдында, Калтырап, күтәрде кулларын,¶Сугышның иң кызган чагында Ташлады кулыннан коралын.* М. Җәлил. **Кул (кулыңны) озайту (озату)** — 1) йодрык кулланып мөгамәлә итү, ору-сугу. *Никадәр кул озайтсалар да, күңелендәге изге йолдызны сүндерергә теләсәләр дә, шагыйрь аның сүнмәгәнен белдерә.* Г. Кашшаф; 2) һөҗүм итү, касд итү. *Озаттылар миңа кул төрле мәлгунь көч, кара көчләр.* Г. Тукай; 3) *к.* кулы озын булу. **Кул остасы** — кул көче белән башкарыла торган нинди дә булса бер эшкә бик оста кеше. *Госманның үз слесаре ялдан әле кайтмаган иде, шунлыктан ул ремонт-механика цехы башлыгы Груздевка шалтыратып, берәр юньлерәк һәм төплерәк кул остасы җибәрүен үтенде.* Э. Касыймов. **Кул очы** — 1) *к.* кул (8 мәгъ.). *Кул очыннан сатып алу;* 2) вак-төяк чыгымнар, кесә чыгымнары. *Акчасын Мәрхабә үзе бирә. Монысын инде кул очына калдырган тиеннәреннән; югыйсә эшләп алганын тулысы белән әнисенә китереп тапшыра.* Г. Әпсәләмов. **Кул пычрату** — үтә вак, көчсез дошманны кыйнау турында әйтелә. — *Кулларымны пычратасым килми, — диде [әхмәди].—Сугып екмыйм. Тик күз алдымнан югал.* Э. Бикчәнтәев. — *Булашсаң [чиновникларның] зурраклары белән булаш, болар белән кул пычратырга ярамый, егетләр.* Х. Кәрим. **Кул салу** — 1) берәр нәрсәгә ия булырга омтылу; талау. *Ышна җире — безнең үз җиребез. --- Бикмурзинның үз җирләренә кул салырга кирәк безгә.* И. Гази; 2) урлау, законсыз үзләштерү. *Дәүләт милкенә кул салу;* 3) һөҗүм итү, җәберләү. *Садыйк кебек бер кешегә --- кул салу — бу инде бабайның зиһененә бер төрле дә сыймый.* Г. Ибраһимов; 4) хатын-кызны көчләргә омтылу. *[Хаҗия Гыйлемдарга:] Инде үз асравыңа кул салу кебек түбәнлеккә барып җиткәнсең.* Т. Гыйззәт; 5) җинаятьчел рәвештә үтерү. — *Миңа үлем җәзасы чыгарыгыз. Үзем җиренә җиткерермен. Болай гына үз-үземә кул сала алмыйм.* Ш. Маннур; 6) берәр эшкә тотыну, шуңа көч кую. *Дни, табигый хәленә төшеп, гадәттәге эшли торган эшләренә кул сала башлады.* М. Гафури. **Кул селкү (селтәү)** — 1) билгеле бер юнәлешкә каратып кул чугын җилпү — күрергә теләмәү, баш тарту яки инкяр итү билгесе. *Кадыйр: „Бар, кит әле, кәефем юк, иртәгә килерсең", — дип, кул гына селкә.* Г. Ибраһимов. *Ул [егет] тагын нәрсәдер әйтергә теләде кебек, ләкин әйтә алмады, кулын гына селтәде: барыгыз, китегез, диюе булды.* А. Шамов; 2) өмет өзү; бөтенләйгә араны өзү. *Утка чыксын бөтен дөньясы дип, Кул селтәдем хәзер барыннан.* Н. Исәнбәт. *Барлык җирдә халык эсерларга, меньшевикларга кул селти.* И. Гази; 3) бөтенләй баш тарту. *Бикмөхәммәт --- эшкә барудан бөтенләй кулын селтәгән.* Г. Насрый. **[Кулга] кул сугу** — 1) *к.* кул чабу. *Бер егет гармонь уйный, Шәриф бии, кул сугу, сызгыру, дәртле хәрәкәтләр.* М. Фәйзи; 2) килешү, үзара ризалашу билгесе итеп, шапылдатып бер-береңнең кулын кысу. *Кыруш туксанны сораган иде, без җитмешне бирдек тә сиксәнгә кул сугып алдык.* М. Гали. *Өйгә кереп сөйләшик тә кулга кул сугышыйк, булмаса.* Х. Сарьян. **Кул сузу** — 1) *к.* кул бирү (1, 2 мәгъ.). *Мин Имәлинең яныма килүен көтмәдем, үзем башлап кулымны суздым.* М. Әмир; 2) *к.* кул озайту (1, 2 мәгъ.). *[Әтиемнең] әнигә кул сузганын, ягъни аны сугу, кыйнау дәрәҗәсенә җиткәнен күргәнем булмады.* М. Гафури; 3) *к.* кул салу (1, 2, 4 мәгъ.). — *[Кулак ияр-ченнәре] төн саен диярлек колхоз байлыгына кул сузмый калмыйлар.* Г. Гобәй; 4) үз кулы белән башкарырга, берәр эштә катнашырга омтылу. *Пычак-пәке кайраулар, утын ваклауларны әйтмим дә. Авыл җирендә теләсә кайсы малай җиде-сигез яшендә андый эшләргә кул суза бит инде.* Э. Касыймов. **Кул сузымы** — үрелеп кул җитәрлек ара. *Сәхнәдән кул сузымы ераклыкта тамашачы утыра.* И. Рәмиев. **Кул сырты белән дога кылу** — бәддога кылу. *Алар [руханилар] мәчеттә безгә каршы кул сырты белән дога кылсалар, --- безнең кулда башка чаралар табылыр.* Г. Ибраһимов. **Кул тарту** — *сир. к.* баш тарту. *Безнең Аю батыр сугыштан да кул тартмас иде, ни чара, аяклар ауга чорналган.* Г. Тукай. **Кул тидерү** — 1) җәзалау яки куркыту максатыннан чыгып ору-сугу. — *Тагын да Фәрхиягә кул тидерәсе булсаң, җаныңны алырмын, бел дә тор шуны.* Ш. Камал; 2) нәрсәне дә булса эшли, эшкәртә башлау. *Кул тидерә, күңел сала торгач, кошчылык фермасының эшләре рәтләнә башлады.* С. Рафиков. *Татар теле грамматикасында байтак мәсьәләләргә әле бөтенләй диярлек кул тидерелмәгән.* В. Хәнгилдин. **Кул тимәгән** — 1) файдаланыла, эшкәртелә башламаган (һәртөрле табигый байлыклар турында). *Кул тимәгән кара урман Калын койма төсле торган.* Э. Исхак. *Бераз эзләп йөргәннән соң, ул [Габделкаюм] әлегә бәр дә кеше кулы тимәгән җиләклек тапты.* М. Гали; 2) тотыла, сарыф ителә башламаган. *Кул тимәгән запас;* 3) гыйффәтле, саф (хатын-кыз турында). *Кеше куллары тимәгән Ярлар таба аласыңмы?* Җыр. **Кул тию** — 1) чистартылу, тазартылу (билгеле берәү тарафыннан). *Өстәл өстендә консервлар, бушап калган тәлинкәләр, хатын-кызлар кулы тимәгән бер кофейник тора.* А. Шамов; 2) ремонтлану, төзәтелү, эшкәртелү турында. — *Безнең кул тигән тракторлар туктарга тиеш түгелләр.* К. Нәҗми; 3) тикшерелү яки яхшыртылу, редакцияләнү турында. *Аңа [романга] әдипнең революциядән соңгы изәт кулы да тигән.* Г. Нигъмәти; 4) *к.* кул җитү (1 мәгъ.). — *Гариза — сукно астында, Кул тими әле һаман.* З. Мансур. **Кул тыгу** — эшкә эзләүсез-сораусыз катнашу (гадәттә әрсез һәм начар кеше турында). *Бәдри мулла --- вак бурыч оешмаларына кулны тыгарга тырыша.* Х. Кәрим. **Кул уйнау** — 1) бик җитез эшләү, эштә осталык һәм җитезлек күрсәтү. *Эшләгәннең кулы уйный, эшләмәгәннең күзе уйный.* Мәкаль; 2) берәр шикле эштә кемнең дә булса актив катнашлыгы булу. — *Димәк, Илбековның урынынан алын уында Тангатаровның кулы уйнаган!* Ә. Фәйзи. **Кул уңае** — эшләргә, эшкәртергә җайлы торыш. *[Шәрифулла] кирпечләрне кырып, чистартып, кул уңаена тәртиплән өеп куйды.* А. Шамов. **Кул хөкеме, кул белән хөкем итү** — судсыз-нисез (гадәттә йодрык белән) җәзалау турында. *Бүген аларның [Закир белән Галимәнең] икесен ике урынга куеп, каравыл куегыз, кул белән хөкем итүче булмасын!* М. Гафури. *Түрәләнергә ярата торган мастерлар берәрсен сүгәргә я кул сузарга теләгәндә, Миңлегалиев башын күтәрә төшеп караса, кул хөкеме ясарга базмыйлар, туктыйлар иде.* А. Таһиров. **Кул чабу** — *к.* алкышлау. *Кызлар гына түгел, бөтен халык Атлыларны котлап кул чаба.* Ф. Кәрим. **Кул эше** — 1) хатын-кызларның бәйләү, тегү, чигү кебек вак йорт эшләре. *Гөлҗамал самоварын куя, ашын пешерә, мич ашларын сала, керен уа, идәннәрен юа, аның өстенә әллә никадәр кул эшләре эшли.* Г. Камал; 2) шундый эш предметы. *Хатын-кыз, нәкъ авылдагыча, кул эшләрен күтәреп, күрше-күләнгә утырмага йөри.* А. Расих; 3) кул эше белән хәзерләнгән төрле әйберләр. *Ул [профессор Фукс], стенага эленгән сөлге, ашъяулыкларга карап: — Мин татар хатын-кызларының кул эшләрен бик яратам инде, җиңги, — диде.* М. Гали. **Кул ябышу (яту)** — 1) берәр эшне (гадәттә физик хезмәт өлкәсендә) аеруча оста, җитез башкару турында. *Якташымны күрдем әле, Ки-*

беттә ипи сата. Гаҗәпләнеп тордым карап — Куллары ничек ята! Н. Гобәй; 2) аерым берәр эшкә сәләтле булу. *Бу машинаны Давыт, төрле иске частьлардан җыеп, үзе ясаган икән. Булыр да, андыйга кулы бик ябыша иде шул аның.* Р. Төхфәтуллин. *Бу эшкә синең кулың бик ята. Нәрсә әйтсәң дә слесарь кеше бит син, Галләм абзый.* А. Шамов; 3) гомумән эшли алу. *Кәрим Төмәндә туган, кулы эшкә ята башлагач, атасы һөнәренә ия булган.* И. Салахов. **Кул ягу** — 1) үтерергә омтылу; кул күтәрү. — *Бүреләр --- Сарыкларга кул якмыйча тик йөриләр.* М. Гафури. [*Талип:*] *„Мин балаларга башка хәлфәләрдән артыграк кул якканым юк“, — дисә дә хаклы булыр иде.* Ә. Фәйзи; 2) нәрсәгә дә булса ия булырга омтылу, кул сузу. *Хәзер, совет вакытында, әллә ниткән буржуй алтыннарына кул ягып, башны җәфага саламыни кеше.* Ш. Камал. **Кул җае** — берәр (гадәттә физик) эшне булдыра алу, шуңа өйрәнү мөмкинлеге. *Юнарга, балта чабарга Бик иртә тотынган ул [балта остасы], Кул җаен сынап караган дүвәл үз йортыннан ул.* С. Хәким. **Кул җитү** — 1) эшләргә өлгерә алу. *Нурия идәннәрне юып, тузаннарны сөртеп, җыештырып киткән иде инде. Барысына да кулы җитә аның!* Г. Әпсәләмов. — *Тактасы әзер, кадагы әзер, койма коясы иде. Кул җитми.* Г. Мөхәммәтшин; 2) берәр начар эшне эшләргә базу, батырчылык итү турында. — *Ничек итеп --- кеше малын таларга кулыгыз җитә!* И. Гази. **Кул җылыту** — 1) алдау-йолдаулы, шикле яки аеруча үзенчәлекле эшләрне башкаруда тәҗрибә туплау. *Мәрхабә, мондый эшләрдә [кызны кияү каршыларга хәзерләүдә] бик күп кул җылыткан хатын кебек, ике сандыкны берьюлы ачып ташлады да кочагы-кочагы белән әйләндерә башлады.* Г. Ибраһимов; 2) шикле юллар белән мал табу. — *Мин күп кешеләрне пешердем, ләкин кул җылыткан өчен түгел, бәлки тиешенчә каплый белмәгәне өчен.* Г. Әпсәләмов; 3) кыйнау, сугу. *Халык гөж килә. Һәрберсенең кул җылытып алырга теләге зур күренә. --- Һичшиксез, стан[овой]ның буен-сынын үлчәячәкләр.* Х. Кәрим. **Кул һөнәре** — кул эшенә осталык. *Кул һөнәрең булгач, кешегә ялынып тормассың.* Ш. Камал. **Кулга алу** — 1) арестка алу, ирегеннән мәхрүм итү. *Искәндәр, контрреволюцион эше ачылып, кулга алынды.* Г. Нигъмәти; 2) үзеңнеке итү, хуҗа, ия булу. *Ал кулыңа, сал куеныңа Гомерлеккә яр итеп.* М. Фәйзи. *Үз язмышын үз кулына алган халык беркайчан да җиңелмәс!* Т. Гыйззәт; 3) үз хисләреңне тезгенләү, үз-үзеңә баш булу. *Үземне көч-хәл белән кулга алып, әкрен генә тамак кырдым.* А. Шамов. **Кулга ияләшү (өйрәнү)** — кешеләр белән яшәүгә күнегү, кешедән өрекми башлау. *Ике фил, хортумнарын күккә күтәреп, безгә сәлам бирделәр. Болар кулга ияләштерелгән филләр иде.* М. Мәхмүтов. **Кулга керү** — үзеңнеке булу, милкеңә өстәлү (башлыча байлык, табыш һ. б. турында). *Кулга акча керү.* □ *дәйтәләр: ныкты тырышып омтыл! Алда зур бәхетең көтә. Белмиләр: ул кулга кергәнче йөрәк тетелеп бетә.* М. Фәйзи. **Кулга төшерү** — 1) нәрсәгә дә булса ия булу. *Һич кулга төшерә алмыйм шул [партия съезды чыгарган] карарларны.* И. Гази; 2) сугышып, басып алу. *Акларның әллә никадәр коралларын, обозларын кулга төшердек.* А. Шамов; 3) әсир, тоткын итү. *Терлекләрне игенгә җибәрмәдек, мал ябучы кулына төшермәдек.* М. Гали. **Кулга төшү** — 1) эзләү, тырышу яки хәйләләү нәтиҗәсендә кулга керү. *Бүген кулыма „Вакыт“ның 70 нче номеры төште.* Г. Тукай; 2) әсирлеккә яки тоткынлыкка төшү. *Кулга төшкән Дутов ялчыларын „Әй“ дидерми эшен бетер син.* Ш. Бабич. **Кулдан килү** — булдыра алу, эшли алу. *Моржа ачу, --- моржа ябу, --- сыерны көтүгә чыгару, кич каршы алу кеби эшләр — һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.* Г. Тукай. *Дни бәгърем, бер дә борчылма, кулдан килгән кадәр тырышам.* А. Шамов. **Кулдан китү (ычкыну)** — югалту, мәхрүм булу турында. *Әллә кулдан киттеләрме Таш пулатлар, бакчалар?* М. Гафури. — *Бу басуны сата күрмәгез, әчендәге хәзинә кулыгыздан ычкыныр.* Дәрдмәнд. **Кулдан төшмәү** — дәвамлы рәвештә бер корал белән эшләү яки берәр нәрсәне тотып тору (йөрү) турында. *Еллар үтте, укҗәям минем кулымнан төшмәде.* Ф. Бурнаш. *Иртәдән башлап кичкә хәтле балта һәм пычкы, китмән һәм көрәк куллардан төшмәде.* Ш. Камал. **Кулдан үтү (кичү)** — 1) билгеле бер хезмәт салынган нәрсәнең шул хезмәт процессыннан чыгуы турында. *Эзе калсын керсез намусыңның Ни үтсә дә синең кулыңнан.* М. Җәлил; 2) берәрсе тарафыннан үтерелү. *Фәхринең кем кулыннан үтүе турында күңелләрдә шөбһә бик кайный иде.* Г. Ибраһимов. **Кулларны җәю** — кулларны, учларын алга карата төшеп һәм югары күтәрмичә генә, як-якка җибәрү — аптырау яки бик гажәпләнү билгесе. *Ветсанитар Галләм абзыйдан сорасаң, ул да кулларын гына җәя.* Ә. Еники. **Кулны күкрәккә кую** — 1) түбәнчелек күрсәтү, гафу үтенү билгесе. *Ул [Хажи] кулларын күкрәгенә куйды: „Борчуымны, ипташ, гафу итәрсез“.* Ф. Кәрим; 2) аеруча чын күңелдән һәм ышанычлы итеп әйтүне белдерә. *Ләкин ышаныгыз, Нургали абый, кулымны күкрәгемә куеп әйтәм, мин Сөләймановтан сезнең хакта андый начар караш ишеткәнем юк.* Ә. Еники. **Кулны тоту** — нинди дә булса эш башкаруны тоткарлау, эшләргә комачаулау. *Чәчү өстендә кулны тотарлык булмасын өчен, утынны да күп итеп ярып куйдылар.* Г. Бәширов. **Кулны (кулын) тик тотмау** — 1) эшсез утырмау, өзлексез эш белән шөгыльләнү; 2) урлашкалау. *Безнең өйдә кулын тик тотмый торган кем бар соң?* А. Шамов. **Кулы корысын (корышсын, коргыры)** — нинди дә булса начар эш эшләгән өчен каргау сүзе. *Кәһәр суксын инде, моны язган кешенең кулы корышсын иде, ходаем.* Ш. Маннур. **Кулы (кулын) озын булу** — урлашкалау, караклык итү. *Җиңең кыска булса булсын, кулың озын булмасын.* Мәкаль. **Кулы ятышлы** — оста, булдыклы. *Гарәфинең скрипкада оста уйнавын, гомумән һәр эшкә кулы ятышлы булуын Муллагали ишеткәне бар иде.* А. Расих. **Кулын куеп китмәгән** — кемлеге билгесез (карак-угры турында). **Кулына карау** — яшәү ихтыяҗлары ягыннан кемгә дә булса бәйле булу. *Мохтар Фатыйманы ят кешеләр кулына караудан коткару өчен чаралар уйлап маташа иде.* Ш. Камал. *Адәм баласы үзе генә дә җаен таба, тик менә бичара хайван гына кеше кулына карап тора.* Ә. Еники. **Кулына шайтан төкергән** — гажәп дәрәҗәдә оста һәм булдыклы. — *Корбый, ничек, малай, болай тиз остардың? Синең кулыңа шайтан төкергәндер. Синең эш ялт та йолт.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Кулыңа (кулына) эләгү** — 1) кинәт кенә яки очраклы рәвештә кемнең дә булса ихтыярында калу, кулына керү. *Дсәр икенче мәртәбә охранка кулына эләгеп, җитмеш бите югалган хәлдә кире кайтарылган.* Г. Нигъмәти; 2) к. кулга төшү (2 мәгъ.). *Дошман кулына эләгү.*

КУЛ II *и. диал.* Инешле ерынты, сулы сыза. *Болар [өч елга] кушылалар да, ул җиргә чаклы кечкенә кул гына булып агып яткан Өзән елганы берьюлы зурайтып җибәрәләр.* Г. Ибраһимов.

КУЛ III *и.* **1.** *бор.* Гаскәрнең гадәттә сыйфаты буенча аерымланган бер өлеше; фланг. *Уң кул урар, сул кул турар, урта кул ук атар.* Мәкаль.

2. Сорт; төр, иш.—*Син татардан беренче кул спец буласың.* Г. Ибраһимов. *Такташ кулаклар һәм алар белән бер кулдан эшләнгән татар милләтчеләрен сурәтләп чыга.* Г. Нигъмәти.

3. Масштаб, зурлык. *Искәндәр чемоданыннан берничә рәсем чыгарды. Арадан берсен, урта кул китап бите кадәресен алып, Гөлсем апага сузды.* Г. Гобәй. *Хәсән зур кулдагы бер фотографический карточканы алды да, аны карап утыра башлады.* Ф. Әмирхан.

4. *с. мәгъ. күч.* Лаек, яраклы. *Бу әйбер кул түгел безгә, кибетче, Минем күркәм йөзем, кершән кирәкмәс.* Дәрдмәнд. — *Безнең абый андый мәҗлес өчен бер дә кул кеше түгел.* Ф. Әмирхан. || Җайлы, уңай, кулай. *Кулак өчен гаҗәп кул кеше инде Шундый бөкре башлы түрәләр.* Һ. Такташ.

Кул башлау — сугыш вакытында гаскәрнең бер өлешен кирәкле моментта иртәп алып китү, атакага күтәрү. *Чын батыр тар җирдә кул башлар, чын чәчән тар җирдә сүз башлар.* Мәкаль.

КУЛАВЫЗ *и. бор.* 1. Таныш булмаган хәтәр урында кичү, үткел, юл күрсәтүче. *Явыздан явыз кем явыз? Ят явына кулавыз!* Мәкаль. *Кулавызсыз юлга кергән юлдан язар.* Мәкаль.

2. *күч.* Пәйгамбәр; остаз; юлбашчы. || Арадашчы. *Кыз, кымыз, кубыз — шайтанга өч кулавыз.* Мәкаль.

КУЛАГАЙ *и. диал.* Ришвәтче. | *с. мәгъ. Кулагай кеше.*

КУЛАЗАК: кулазак арба — бүрәнә тарттыру өчен җайланган ике тәгәрмәчле арба. *Кулазак арба юл бозар, ярты мулла ил бозар.* Мәкаль. *Гобәйдулла --- тугыз аршынлы бүрәнәләрне бер ялгызы кулазак арбага салып кайтты.* Г. Ахунов.

КУЛАЙ *с.* Уңайлы, җайлы; урынлы, лаеклы. *Арсланов мондый кулай мәкальнең телгә килүенә кәефләнеп елмая.* И. Салахов. *Озын сүзнең кыскасы шул: ир кешегә иң кулай һөнәр ул балта эше.* Р. Төхфәтуллин. || Әйбәт; булдыклы, яраклы (кеше турында). — *Сез Хәдичәгә тулысынча ышана аласыз. Иң кулай әлемтәче ул.* А. Расих.

КУЛАК *и. тар.* Ярлы-ялчы көче белән файдаланучы бай крестьян, байгура. *Кулаклар, икмәк яшереп һәм икмәк белән спекуляция ясап, илдә икмәксезлек кыенлыгын көчәйтәләр.* М. Җәлил. *Авыл яшьләрен аздыра дип, кулаклар яшь укытучыны чак кына үтерми калганнар.* И. Гази.

КУЛАКЛЫК *и.* Кулакларга хас сыйфатлар. — *Рамазанны кулак диләр. Аның кулаклыгы инде, --- җир чәчүе дә юк.* Г. Толымбай.

КУЛАЛМАШ *рәв.* 1. *к.* кулалмашка (1, 2 мәгъ.). *Зәйнулла белән Шәрәфи кулалмаш ашлык суктылар, бергәләп мал-туар үстерделәр, бергәләп урман кистеләр.* Г. Галиев.

2. *и. мәгъ.* Пардаш, ярдәмче. *Кулалмаш булып ярдәмләшү.*

КУЛАЛМАШКА *рәв.* 1. Ике кеше эшли торган эштә ярдәмгә, парга. *Кулалмашка кул талмас.* Мәкаль.

2. Бер эш көненә бер эш көне (кулга-кул) түләү шарты белән эшләшеп. — *Җәй көне миңа көнгә-көн кулалмашка чыгарсың, кая, үзем эшләп ташлыйм,— дип, Шәңгәрәй бура бурап бирде.* Г. Ибраһимов.

КУЛАСА *и. диал.* Су агымының көче белән әйләнә торган махсус тәгәрмәч, зур чарык. *Тегермән куласасы.* □ *Дт-дөнья куласа: әйләнә дә бер баса.* Мәкаль. *Вак-вак тамчылардан торган су турбиналарның авыр куласаларын әйләндерә.* Г. Галиев. || Гомумән калаклы тәгәрмәч, калаклы вал. *Алга! — диде тиен куласа эчендә, И чаба тиен иртә дә, кичен дә.* Г. Афзал.

КУЛ-АЯК *и. к.* аяк-кул. *Габделхәй урта яшьтә, буе кыска, башы зур, колаклары киң, кул-аягы тупас бер кеше иде.* Ш. Камал.

КУЛБАУ *и. диал.* Җепкә гәрәбәләр, мәрҗәннәр тезеп ясалган беләзек, чылбыр беләзек. *Егет тавышын кыз ишетсә, шылтыратыр кулбавын.* Җыр. *Энҗе дә мәрҗән кызларның кулбавы; Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.* Җыр.

КУЛБАШ *и.* 1. Беләкнең калак сөягенә тоташкан урыны. *Кулбашка йөк салу.* □ *Җамали кулбашын тотып күрсәтте: — Атакага барганда менә монда штык белән чаптылар.* М. Гали. *Чиләк күтәреп барганда кулбаш сөякләрем шытыр-шытыр килә иде.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Күлмәк һ. б. ш. киемнәрнең кулбаш турысы. [*Бәдри*] *мич алдында күлмәгенең кулбашына ямау салып утырган Җәмиләне дә буш калдырмады.* М. Гафури.

КУЛГА-КУЛ: кулга-кул тотынышу (тотыну, бирү) — 1) бер-берсенең кулын үзара тотышу. *Алар [малайлар], кулга-кул тотынышып, икәү бергә бик озак шудылар.* А. Шамов; 2) *күч.* якын дусларча, бик килешеп мөгамәлә итү. *Мин Татарстанда руслар белән татарларның ничек кулга-кул тотынышып эшләүләрен сөйлим.* Г. Гали. *Хәлфә, шәкерт — һәммәсе кулга-кул биреп, ярдәмләшеп барырга кирәк.* Г. Ибраһимов.

КУЛДАН-КУЛГА *рәв.* Кешедән кешегә, берәүдән икенчегә, өченчегә һәм башкаларга. *Кызлар, кулдан-кулга йөртеп, рәсемне карыйлар.* А. Әхмәт. *Кәгазь шунда ук кулдан-кулга китте.* И. Гази.

КУЛДАШ *и. сир.* Эштә ярдәмче, бергә эшләүче. *Карендәшсез кешеләрнең сердәше юк, Дошманнарга каршы торса, юлдашы юк, Күңелендәге эшне кылса, кулдашы юк.* М. Колый.

КУЛДАШЛЫК *и.* Кулдаш булу. *Шуңа күрә Зөннүн башта Гыймранны, кулдашлыкка алмыйча, борып җибәрде.* Каз. утл.

КУ'ЛИ *и.* Көнчыгыш һәм Көньяк Азия илләрендә кара эшче, гадәттә кул арбасына җигелеп, йөк яки кеше ташып йөрүче йөкче. *Сөйләп китте: ничек бөтен гомерен Кули булып чабып үткәргән ул [карт].* Н. Арсланов. — *Ә мин бүген, кули арбасына кәпрәп утырып йөргән янки кебек, синең аркаңа атланып йөрдем.* Г. Әпсәләмов.

КУЛИНАР *и.* Оста пешекче; аш-су белгече.

КУЛИНА'РИЯ *и.* Аш-су хәзерләү осталыгы. *Каракүз кулинария курсында укымаса да, аш пешерүнең хикмәтләрен өйрәнеп үскән иде.* И. Салахов.

КУЛИ'СА *и.* Сәхнәдә стенаны сурәтли торган яҗи рәсемле зур киндер элү өчен хезмәт итә торган зур куна, щит. *Артистлар --- сәхнәдә вакытта Т. Гыйззәт һәрвакыт кулисага яшеренеп --- рәхәтләнеп көлеп тора иде.* Х. Сәлимҗанов.

КУЛКУБЫЗ *и.* Скрипканың бер төре. *Кулкубыз тартсаң — көй чыга, бүрәнә тартсаң — өй чыга.* Мәкаль.

КУЛЛАМА *и.* Салма катыш туралган ит. *Куллама пешерү өчен симез ат, сыер яки сарык ите алына.* Хал. ашлары.

КУЛЛАНМА *и.* Инструкция, күрсәтмәләр җыелмасы. *Методик кулланма. Эш кулланмалары.* □ *Бүгенге җыелышның көн тәртибендә беренче [мәсьәлә] — кантон вәкиленең кулланмалары.* Ф. Бурнаш.

КУЛЛАНУ *ф.* Берәр процесс яки эш максатлары өчен файдалану. *Көч куллану. Яңа метод куллану. Хәйлә куллану.* □ *Каюм белән Мәдинә дигән хатын да корал куллана алырлык иптәшләр.* Ш. Камал. *Мәҗит Гафуриның мәсәл жанрын куллануы 1908—1915 елларга туры килә.* М. Җәлил.

КУЛЛАНЫШ *и.* Нинди дә булса предметның яки метод, ысул һ. б. ш. ның эш, хезмәт процессында яки көрәштә файдаланылуы. *Кулланышта булу. Кулланыштан чыгу.* □ *Кәгазь --- бик күп төрле кулланыш таба.* Робинзон әзл.

КУЛЛАП *рәв.* Билгеле бер (билгеле сандагы) кул белән. *Бер куллап.* □ *Әхмәт чанага утыргач та, сулагай куллап чыбыркыны әйләндерә-әйләндерә, туры кашка атын ныклап каезлый башлый.* Ш. Камал. *Нәҗип, дулкынланып, Хәлилнең кулын ике куллап кысты.* Г. Гобәй.

КУЛОН I *и.* Муенсага тагылган кыйммәтле таш яки бизәкле пыяла кисәге — бизәнү әйбере. *Өстенә бик тар күлмәк кигән, муенына нечкә алтын чылбыр белән түгәрәк кулон таккан - - - бер кыз белән Мансур баскычтан менеп килә иде.* Г. Әпсәләмов.

КУЛОН II *и. физ.* Электр тогы микъдарын үлчәү берәмлеге.

КУЛСА *и.* Кул белән эшләтелә торган механизмның тоткасы; шундый механизмның үзе — кыска рычаг яисә рычаглар системасы. *Өйрәнчек тимерчегә дугайлы берничә озын теш ясап беркетүе, тырманың төшергеч-күтәргеч кулсасын төзәтүе хәтсез* [*авырга*] *төште.* Каз. утл.

КУЛСЫЗ *с.* 1. Кулы булмаган, чулак (кулы үзелгән яки кулы гарипләнгән). *Башкорт егет кулсыз җиң очын ипләп кенә кесәсенә тыкты.* Г. Гобәй.

2. *күч. рәв. мәгъ.* Эшләүчесе, ярдәмчесе булмаган хәлдә. *Ә монда анасы белән хатыны бер кулсыз калдылар.* Г. Ибраһимов.

КУЛСЫЗ-АЯКСЫЗ *рәв.* 1. Аягы да, кулы да булмаган килеш. *Белсен дошман: кулсыз-аяксыз да Тез чүгәчәк кеше түгел без.* М. Җәлил.

2. Бөтенләй ярдәмсез, ярдәмчесез. — *Зинһар дип әйтәм, кабер якасына баскан атам белән анамны кулсыз-аяксыз калдырмагыз.* Ф. Бурнаш.

КУЛТАМГА *и. бор.* Имза мәгънәсендә йөри торган тамга. *Култамга кую.*

КУЛТАЯК *и.* Таянып йөрү һ. б. максатлар өчен кыска таяк.

КУЛТЫК *и.* 1. Беләкнең югарыгы өлеше белән ян арасы. *Култыкка тыгу. Култыкта тоту.* □ *Бер култыкка ике үгез башы сыймавы мәгълүм.* Г. Тукай. *Сәлим мылтыгын култыгына кысты.* Г. Гобәй. || Инбаш бөгелешенең эчке ягы. *Култыктан алу. Култыктан тоту. Култыктан эләктерү.* □ *Сәлимә акрын гына, ләкин җитди генә култыгын Рокыя кулыннан ычкындырды.* Ф. Әмирхан. || Беләк белән гәүдә арасы, куен. *Әткәй, мине иркәләп, култыгына алды.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. к.* култыкса. *Садыйк, кулларын креслоның ике як култыгына куеп, аз гына Галләметдингә табарак сузылды.* Ш. Камал.

3. Култыкка сыярлык күләм үлчәве (култыкка кыстырып ташырлык әйберләр турында). *Капка башына кәҗә тәкәсенең баш сөяге белән бер култык печән асылган булыр.* К. Нәҗми.

4. Диңгез, күл һәм башка сулыкларның коры җиргә уенты рәвешендә кереп торган өлеше. *Карабугаз-гол култыгы. Фин култыгы.* □ *Бәсер елгасы — бәләкәй елга, әмма ләкин, бик боргалана-боргалана акканга күрә, култыклар күп үзендә.* Ш. Камал. *Көчле агым боз кисәкләрен култыклардан кагып чыгара.* Э. Фәйзи.

5. Аерым мәйданнарның төп өлешләреннән аерылыбрак торган бүлемтек, мәйданчык. *Урам хәрәкәте аз; сәләмәрәк урам, шәһәрнең тынрак култыгы.* Ш. Камал. || Нинди дә булса ышык урын. *Чүлмәк тә чүлмәк сары май Мич култыгында эридер.* Җыр.

Култык асты — 1) *к.* култык (1 мәгъ.). *Нәфисә - - - әйберләрен култык астына кыстырды да урыныннан торды.* Г. Бәширов; 2) киемнең култык турысы. *Минем эчке күлмәгемнең култык астында кечкенә бөти кебек әйбәтләп тегелгән йөзәр сумлык ике кәгазь.* Г. Ибраһимов. **Култык таягы** — аяксыз яки аксак кешеләргә култык белән таянырга махсус җайланмасы — тияге булган озын таяк. *Арслан, култык таякларына таянып, иртүк капка төбенә чыгып утырды.* Г. Ахунов.

КУЛТЫК-КУЛТЫК *с.* Рәттән торган култыклар рәвешендәге. *Култык-култык сулар ялтырап аста кала, пароходлары йөреп тора, саллары агып бара.* С. Рафиков.

КУЛТЫКЛАНУ *ф.* Култык сыман булу, эчкә кереп тору. *Мичнең икенче бер кырыендагы култыкларына тора торган бер җиргә чынаяклар, чәйнекләр куелган булалар иде.* М. Гали.

КУЛТЫКЛАУ *ф.* 1. Култыкка алу, култыкка кыстыру. *Яшь хатын, портфелен култыклап, йөзе, күз карашы белән бераз назланды.* Г. Ибраһимов.

2. Култыктан тоту; кулны башка берәүнең култыгыннан үткәреп эләктерү. *Тау асты битеннән ике кеше бер адәмне ике яктан култыклап китерәләр.* Ш. Камал.

КУЛТЫКЛАШУ *ф.* Бер-береңне култыклау. *Кызлар, култыклашып, коридорга гына чыкканнар иде.* Ф. Әмирхан.

КУЛТЫКСА *и.* 1. Басма, баскыч, балкон һәм күперләрдә кул белән таянып яки тотынып тору өчен ясалган арата. *Басмага култыкса ясау.* □ *Суфия ханым, баскыч култыкссасына тотынып, туктап калды.* Г. Әпсәләмов. [*Гәрәй*] *култыкссалары җимерелеп төшкән агач күперне күрде.* А. Гыйләҗев. || Әйберләр кую өчен баскыч рәвешендәге өстенә ясалган киштә. *Сәгыйть баскыч төбенә килеп утыруга, култыксага каплап куелган чиләк чылтырап китте.* Р. Төхфәтуллин.

2. *сир.* Култык таягы. [*Гәрәйша*] *үз куллары белән үзенә аяк ясап киде дә култыксаларын өй чормасына ыргытты.* Ш. Маннур.

КУЛУАР *и.* 1. Съездлар, киңәшмәләр һ. б. үткәрелә торган бинаның утырышлар залыннан тыш булган бүлмәләре, бүлемнәре.

2. Парламентта, съездда рәсми булмаган сөйләшүләр, киңәшүләр, очрашулар турында. *Кулуар сөйләшүләре.*

КУЛЪЮГЫЧ *и.* Кул һәм бит юу өчен махсус җайланган (гадәттә төбендәге тишеккә клапан куелган) савыт. *Кулъюгычка су салу. Кулъюгычны стенага (баганага) беркетү.*

КУЛЪЯЗМА *и.* 1. Кулдан язылган текст. *Китапның кулъязмасы.* □ *Габдулла, Әхмәтша хәлфәгә булышып, аның „Төрки теле" дигән кулъязмасын күчереп биргән иде.* Ә. Фәйзи. *Бибигамбәр абыстай - - - карты Хөмәгеннән калган кулъязмаларны укый.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Кулдан язылган. *Кулъязма китап.* □ *Кулъязма мирасыбыз — халкыбызның байлыгы.* Каз. утл.

2. *к.* кулъязу. *Кулъязмасы да бертөсле: Сырмалы да бормалы.* М. Җәлил.

КУЛЪЯЗУ *и.* Почерк, язу рәвеше, кул. *Ул хат үтерелгән Зөләйханың үз кулы белән язылган булырга кирәк. Номер хуҗасы Зөләйханың кулъязуын белә икән.* З. Бигиев. *Мостафа Нәгыймнең кулъязуын таныды.* Ш. Камал.

КУЛЪЯУЛЫК *и.* Битне, муенны һ. б. сөртеп алу өчен гадәттә кесәдә йөртелә торган махсус тукыма кисәге. *Абзый кесәсеннән - - - баш яулыгы кадәр кулъяулык чыгарып, маңгаен, муенын сөртә башлады.* Ә. Фәйзи.

КУЛЬМИНАЦИОН *с.* Кульминация ноктасына җиткән, шул ноктаны тәшкил иткән. *Йолдызның кульминацион торышы. Вакыйгаларның кульминацион куеруы.* □ *Рушат иң авыр, кульминацион ноктаны кичерде.* М. Мәһдиев.

КУЛЬМИНА'ЦИЯ *и.* 1. *астр.* Күк җисеменең меридиан турысыннан үтү моменты.

2. *күч. кит.* Вакыйгалар үсешенең иң югары, иң киеренке моменты. *Кульминация ноктасы.* □ [*Инто-*

нациядән] без шигырьнең поэтик фикере ничек үсүен, киңәюен, кульминациясенә күтәрелүен --- тоя идек. Г. Кашшаф.

КУЛЬТ *и.* 1. Дини табыну, гыйбадәт һәм шуңа бәйләнешле дини йолалар. *Ислам культы. Тәңре культы.*

2. *күч. кит.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса табыну, багыну турында. *Шәхес культы. Мәхәббәт культы.* □ *Ул [буржуазия] „саф милли“, „саф борынгы халыкчанлык“ культын алга сөрде.* М. Җәлил.

КУЛЬТ- Кушма сүзләрдә „культурага бәйләнешле“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **культбүлек, культпоход, культорг, культтовар, культработник.** □ *— Культсекция нишли? Культфондыгыз кайда? Кая китә аның акчасы?* М. Җәлил.

КУЛЬТИВА'ТОР *и.* Сөрелгән җирне йомшарту, чәчүлек җирен чүп үләннәрдән тазарту өчен кулланыла торган авыл хуҗалыгы коралы. *Хәзер [Нәфисә] Гөлсемнең олы юл киңлеге җирне иңләп барган культиваторына, аның артыннан ияргән бик күп тырмаларга куанып карап тора.* Г. Бәширов. *Беренче трактор кузгалып китте. Аның артыннан сабаннар, чәчкечләр, тырма-культиваторлар кузгалып китте.* Н. Фәттах.

КУЛЬТИВА'ЦИЯ *и.* Сөрелгән туфракны йомшарту, каты кәсләрне ваклап көпшәкләндерү эше. *Район агрономы, үзенең кышкы вәгъдәсе буенча, „Ватан“ пионерлары җиренә үзе карап торып культивация ясатырга килгән иде.* Г. Гобәй.

КУЛЬТИВА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Культивация ясау. *Мин төшкә хәтле үк тырмалап бетерәм. Аннары культивациялим, шунда бер очтан икенче кат тырмалап узам.* Г. Бәширов.

КУЛЬТУР *с. сир.* 1. Культурага бәйләнешле, культурага мөнәсәбәтле. *Культур революция. Культур эшчәнлек.*

2. Культуралы, мәдәни. *Культур тормыш.* □ *Туй дисәң дә туй булыр, Культур, таза, күңелле Килә чәккә юл булыр.* Ф. Бурнаш. *Бер якта — бик әшәке, икенче якта — бик иҗаби, культур, эшлекле типлар.* М. Җәлил.

КУЛЬТУ'РА *и.* 1. Кешелек җәмгыятенең җитештерү, иҗтимагый һәм рухи тормыш өлкәсендәге казанышлары системасы. *Культура төзелеше. Культура байлыгы. Культураны күтәрү.* □ *Билгеле, пролетариат культурасы моңарчы үсеп, баеп килгән тулай кешелек культурасы нигезендә туа.* М. Җәлил. *Патша хөкүмәте милли культураның һәртөрле күренешен буарга омтылды.* М. Гали.

2. Берәр эшчәнлек өлкәсендә осталык, тәртип, техника һәм оешканлыкның югары үсеш дәрәҗәсе. *Хезмәт культурасы. Үз-үзеңне тоту культурасы.* □ *Дөнья классикларының иҗатларын өйрәнү һәм югары музыка культурасын үзләштерү нигезендә эшләнгән әсәрләр татар музыкасын баеттылар.* М. Җәлил.

3. Файдалы хайванны асрау, үрчетү яки үсемлекне үстерү эше. *Бакчачылык культурасы.* □ *Кырыгый милләш Татарстанның күп кенә районнарында очрый, ләкин культурага ул тик сугыштан соңгы елларда гына кертелде.* Бакчачылык.

4. Асрала торган хайван яки үстерелә торган үсемлек. *Инде колхоз басуларында көнбагыш, киндер һәм җитен кебек соң өлгерә торган культуралар да чәчелеп бетте.* Г. Галиев.

Культура сарае (йорты) — культура учреждениеләрен берләштергән оешма һәм шуның эш бинасы. *Шәһәрнең урта бер җирендә, киң мәйданга каршы, мәһабәт культура сарае тора.* Г. Әпсәләмов.

КУЛЬТУ'РАЛАШУ *ф.* Культуралылану, культуралыга әверелү. *Идел буе төркисе --- культуралашкан язма әдәби тел була.* Каз. утл.

КУЛЬТУ'РАЛАШТЫРУ *ф.* 1. Культуралы итү. *Бу әсәрдә --- типлар артыграк культуралаштырып бирелгәннәр.* М. Гали.

2. Авыл хуҗалыгы культуралары үстерү өчен эшкәртү (җир турында). *Сәрдә культуралаштырылган җирләрдә үсә.* Робинзон әзл. || Авыл хуҗалыгы культурасына әверелдерү. *Кеше беренче мәртәбә [моннан 6—8 мең еллар элек] культуралаштыра башлаган бодай орлыгы --- форма ягыннан гына хәзергегә охшаш.* М. Абдрахманов.

КУЛЬТУ'РАЛЫ *с.* Культураны үзләштергән; культура кагыйдәләренә ярашлы, культурадан файдаланучы. *Культуралы булу. Культуралы кеше.* □ *Латыйповның үзен сәхнәдә культуралы итеп, тыйнак тотуы тамашачыда матур истәлек калдырды.* И. Рәмиев. *Безнең алда культуралы таза тормыш кору бурычы тора.* Г. Гобәй. || *рәв. мәгъ.* Культура кагыйдәләренә ярашлы рәвештә. *Культуралы күңел ачу һәрбер совет гражданының мәгънәви бурычларыннан берсе.* Ш. Камал.

КУЛЬТУ'РАЛЫЛЫК *и.* Культуралы булу.

КУЛЬТУ'РАСЫЗ *с.* Надан, кыргый, вәхши. *„Бәхетсез егет“ драмасында Кәрим бай культурасыз, надан, комсыз, саран, вакчыл иттереп гәүдәләндерелә.* М. Гали.

КУЛЬТУ'РАСЫЗЛЫК *и.* Культурасыз булу.

КУЛЬТУ'РАЧЫЛЫК *и.* Культураны пропагандалау һәм тарату эше. *Культурачылык белән шөгыльләнү.*

КУЛЬТУ'РНИК *и.* 1. Культура (аң-белем, грамота) тарату эшлеклесе. *М. Гафури --- казакъ далаларында культурник булып каңгырып йөрүләрен --- сөйләп утырды.* Ш. Камал.

2. (Ял йортлары, санаторийлар һ. б. да) ял вакытында уеннар, җыр-биюләр оештыручы җитәкче.

КУЛЬТУ'РНИКЛЫК *и.* Культурник булу; культурник эше. *Культурниклык белән шөгыльләнү.*

КУМЫШКА *и. гади с. к.* самогон. *Трактирчы, өстәлне сөртеп алып, өстендә колмаклары һәм сарымсаклары йөзеп йөргән өй сырасы һәм зур чүлмәк кружка белән кумышка китереп куйды.* М. Гали.

КУНА *и.* Берничә тактаны җепсә белән беркетеп эшләнгән яки бер киң тактадан гыйбарәт кухня җиһазы. (ипи әвәләү, токмач басу, кисү һ. б. өчен кулланыла). *Идән --- токмач кунасы шикелле чиста юылган.* Г. Гобәй. *Хәзер инде аңа [Мәдинәгә] заводның -ғ- менә дигән тоташ куна булырлык киң такталарына кадәр якын.* М. Хәсәнов.

Куна такта (тактасы) — *к.* куна. *Тәрәзәнең бер өлгесе ватылды. Көндез мендәр тыгалар, кич куна такта каплыйлар.* Г. Ибраһимов. *— Куна такталарында чәкчәк турыйлар; гөбәдия камырын нәрсәгә җәясең?* Ә. Фәйзи.

КУНАК *и.* 1. Махсус чакыру яки йола буенча берәр кешегә, гаиләгә яки илгә күрешү, дуслык күрсәтү яисә танышу өчен кыска вакытка килгән шәхес. *Кунак килү. Кунак җыю.* □ *Туй күрке кунак белән.* Мәкаль. *Кунак, өйалдында, ишек төбендә бераз кагынганнан соң, хуҗалар белән бергә өйгә керде.* А. Шамов. *— Соң инде кунак белән шулай сөйләшәләрме?* һ. Такташ. | *с. мәгъ.* [*Хәйдәрнең*] *үз өенә килеп кергән кунак кешегә берьюлы алай каты бәреләсе килмәде.* Г. Бәширов.

2. *кыек килеш форм.* Махсус кунак булу күренеше турында. *Кунакка бару. Кунакка чакыру. Кунакта булу.* □ *Апам белән җизни беренче рәт кунакка килделәр.* М. Гафури. *Ул өйләндереп тә бер рәхәтләнеп кунакка йөреп калмагач, дөньяның ни рәхәте бар.* Г. Камал. || *күч.* Кыска вакытлы отпуск. *Бер заман бер крестьян солдат хезмәтеннән кунакка кайта.* Г. Гобәй.

Кунак булу — кунак сыйфатында сыйланып, хөрмәтләнеп беркадәр вакыт уздыру. *Мәликәнең бит кунак буласы да, кодагый булып йөрисе дә килә.* А. Шамов. **Кунак итү (кылу)** — кунакка тиешле булган сый-хөрмәт күрсәтү. — *Иремнең иң якын дусты, кунак итмичә җибәрер хәлем юк.* Г. Бәширов. [*Җәләл*] *бүген Зарифка аерым илтифат күрсәтмәкче, кунак кылмакчы иде.* Г. Ибраһимов. **Кунак йорты (сарае)** — килгән-киткән кунаклар өчен салынган махсус йорт, сарай, гостиница. *Бәлки, ул хәлифәнең кунак сараедыр.* Ф. Әмирхан. **Кунак йөрү** — кунак булып йөрү (бару, килү); кунактан кунакка йөрү. *Кызу чагы ләкин эшегезнең, Килешмәстер кунак йөрергә.* Ш. Маннур. **Кунак төшү (төшерү)** — махсус хәзерләнгән урынга кунак булып килү (кунак китерү). *Кунак төшсә, йортка ямь.* Мәкаль. **Кунак уздыру** — кунак чакырып мәҗлес уздыру. *Бу кыйбатчылык елны кемнең кунак уздырып торасы килсен соң?* Г. Камал. **Кунак өе (бүлмәсе)** — кунакларны сыйлау, яткыру өчен махсус өй, бүлмә. *Бу кунак өе булганга гына түгел, кызлы өй булганга бигрәк тә пөхтә.* Г. Ибраһимов. **Кунак өндәү** — кунакка дәшү. [*Маһруй:*] *Бүген гимназиядән чыкканнан бирле менә Галиев белән кунак өндәп йөрибез.* Ф. Әмирхан. **Кунактан кунакка йөрү** — бербер артлы берничә кешедә кунак булып йөрү.

КУНАК-КУНАК *рәв.* **1.** Бер-береңә кунакка барып. *Кунак-кунак йөрү.* □ *Өйгә кайткач, тагын кунак-кунак йөрешербез әүвәлгечә без.* М. Җәлил.

2. *и. мәгъ.* Бер-береңә „кунакка барып“ уйный торган уен. *Сеңелләрем бер-берсен чакырып, кунак-кунак уйнарга тотындылар.* З. Бәшири.

КУНАКЛАУ I *ф.* **1.** Кош-корт турында: берәр биек урынга очып менеп утыру. *Чебешләр инде тавыктай зур булдылар. Колгага менеп кунаклыйлар да рәхәтләнеп йоклыйлар.* А. Алиш. *Сугу машинасы эштән туктагач кына, күгәрченнәр бармак калынлыгында йомшак тузан белән капланган ояларына кунаклап гөрләшә башлыйлар.* Г. Әпсәләмов. || Төн үткәрү өчен берәр биек урынга куну (тавыклар турында). *Тавыклар кунаклый башлагач, кунак килми торган иде элек.* Ф. Хөсни.

2. *күч.* Биегәеп торган берәр урынга менеп утыру. *Илдар әллә кайчан [йөк башына] үзе менеп кунаклаган иде.* Г. Гобәй. *Хәлим яңадан көймә койрыгына менеп кунаклады.* И. Гази. || Урын алып утыру. [*Директор*] *тугызда һәрвакыт креслосына кунаклаган буладыр иде.* Ш. Камал. — *Утыр, дигәч, утырмаган булган иде* [*Зөфәр*], *кызлар килгәч, бик матур килеп кунаклады.* М. Фәйзи.

КУНАКЛАУ II *ф. сөйл.* Кунак булып бераз тору. *Һәр җәйдә бер мәртәбә үзләрендә кунакта була торган вә бер мәртәбә аларга кунаклап барыла торган бу егет белән Габделбасыйр күптән инде уптәш вә дус иде.* Ф. Әмирхан. [*Әнинең абзасының*] *ел да бер-ике мәртәбә бик шәп атларда килеп, кунаклап китүен беләм.* Ш. Камал.

КУНАКЛАШУ *ф. сөйл.* Бер-береңне кунакка чакыру, кунакка йөрешү. *Ара төзәлде. Хәзер инде ата-ана, ул-килен булып катнашып, кунаклашып йөриләр.* Г. Ибраһимов.

КУНАКЛЫ *с.* Кунагы булган, үзенә кунак килгән. *Кунаклы өйгә кот куна.* Мәкаль.

КУНАКЛЫЙ *рәв. сир.* Кунак булып, кунак итеп. *Кардәш-ыруга кунаклый йөрү.* □ — *Шушы гыйфрит сезне безгә кунаклый алып килер.* Әкият.

КУНАКЛЫК *и.* **1.** Кунак булу, кунак булып хисаплану дәвере. *Хөсәен үткән ел ук кайткан иде. Илтәшенең хәзерге кунаклыгы солдаттан кайтышы иде.* Ш. Камал.

2. *с. мәгъ.* Кунакка (кунакларга) җитәрлек яки шулар өчен билгеләнгән. *Кунаклык аш. Кунаклык нигъмәт.*

КУНАК-ТӨШЕМ *җый. и.* Һәртөрле кунаклар һәм мәҗлес җыюлар. *Быел байлык шәп, кунак-төшем күп буласы иде.* Г. Ибраһимов.

КУНАКХАНӘ *и. к.* кунак йорты (сарае). *Ярминкәнең нәкъ үзәгендә, Кушъяктагы кунакханә каршысында иде бу бакча.* И. Рәмиев.

КУНАКЧА *и. к.* куначa I. *Кунакчага кунаклау.* □ *Тавыклар кунакчаларыннан очышып төштеләр.* Дәрдмәнд.

КУНАКЧАН *с. диал. к.* кунакчыл. *Кунакчан кеше.*

КУНАКЧЫЛ *с.* Килгән кунакны хуп күрүчән, яхшы сыйлаучан, кунак чакырырга яратучан. *Кунакчыл йортта кунак бар.* Мәкаль. — *Хәзер самовар куеп җибәрербез. Ләззәтләп бер чәй эчеп алырбыз!* — *диде* [*Сәлүк суфый*] *кунакчыл тавышы белән.* Ә. Фәйзи. *Бу җирләр бик күңелле икән, ит-кымыз мул. Халкы кунакчыл.* И. Салахов.

КУНАКЧЫЛЛЫК *и.* Кунакчыл булу. *Урманбаш авылы кешеләренең кунакчыллыгы бар, килгәнне-киткәнне сыйлап җибәрергә яраталар.* Ф. Хөсни.

КУНА-ТӨНӘ *рәв.* Кунып-төнәп, төннәрен куна-куна. *Савучы кызлар - - - җәйләүдә куна-төнә гомер кичерделәр.* С. Рафиков.

КУНАЧА I *и.* Йорттагы кош-корт менеп кунакласын өчен махсус куелган киштә (шикмә). *Куначадагы әтәч, канат кагып, актыккы мәртәбә кычкыра да җиргә төшә.* А. Шамов. *Яңа фермада - - - тавыкларны көндез кунаклатмыйлар. Бер клапанга бармак белән басуга, куначалар механик рәвештә стена буена җыелалар.* С. Рафиков.

КУНАЧА II *и. диал.* Ак бүлмә, кунак бүлмәсе. *Чыбылдыккайларым чуп-чуар; Минем куначамда кем кунар?* Җыр.

КҮНГАК *и. диал.* Умарта авызында бал кортларына килеп куну һәм очып китү өчен җайланган такта бусага.

КУНДЫРУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* куну (1—4 мәгъ.). *Өйдә кундыру. Тузан кундыру. Агачка кундыру.*

2. *гади. с.* Тиз генә һәм каты итеп, авырттырып сугу, бәрү. *Менә шунда яңакка шалт итеп кундырдылар берне.* М. Гафури. *Өченче бер кыз: „Я, әйт, кем суклы?“ — дип, минем аркага берне кундырды.* М. Гали.

КУНУ *ф.* **1.** Очып килеп берәр биек урынга утыру (басу) (кошлар, канатлы бөҗәкләр һ. б. турында). *Очып йөргән мәгърур тау бөркете Килеп куна курше кыяга.* Ф. Кәрим. *Өй түрендәге бакчаның Былбыл кунган гөленә.* М. Фәйзи. || *күч.* Һавадан очып килеп бәрелү (җансыз әйберләр турында). [*Фазыл*] *иелеп калды, балчыгым икенче бер малайның маңгаена кунды.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр өсйөзгә ябышу, утыру (һавада йөзеп йөргән тузан, дым һ. б.ның кисәкчәләре турында). *Тузан куну.* □ [*Әхмәдулланың*] *бөтен өс-башын буран каплаган, хәтта керфекләренә дә кар кунган иде.* А. Шамов. *Таң чыклары тамчы булып Гөлгә кунганнар.* Ә. Ерикәй.

3. Кайда да булса тукталып төн үткәрү, йоклап чыгу. *Кич куну. Төн куну.* □ *Ике урында ат аша-тып, Чыпчыкта куныпбыз, Бәдри абзый белән Габдулла төгәл бер тәүлек дигәндә Казанга килеп җиттеләр.* Ә. Фәйзи.

4. Бергә кочаклашып йоклау, төн үткәрү (егетләр һәм кызлар яки ирләр һәм хатыннар турында). *Хәйрулла малае әйткән, җиңги, дигән, Нәгыймәне мин яратам, бүген кич аңа кунарга керәм, урам як тәрәзәсен бикләмәсен, дигән.* Г. Ибраһимов.

5. *хәл ф. форм.* **куна**. Кунарга (дип). *Ат ашатырга тугайга куна йөрү.* □ *Таня куна килгәнлеген әйтте.* Г. Әпсәләмов. || Даими рәвештә кунып. *Элек мин мәдрәсәдә куна ятып укый идем.* М. Гафури.

КУНУ-ТӨНҮ *ф.* Кунарга, ял итәргә тукталгалау; дәвамлы рәвештә, тәүлекләр буенча берәр билгеле урында яшәү. *Юлда кунып-төнеп йөрү.* □ [*Ялайның*] *атасы-анасы һәм кунарга-төнәргә бер билгеләнгән урыны да юк иде.* Ак юл. *Өч-дүрт кеше кунып-төнеп торырлык матур гына өй дип әйтерлек була бу.* Ш. Камал.

КУНЫК *и.* Нинди дә булса өсйөзгә ябышкан коры бер матдә катламы. *Кыздырганда бакыр кара куныкбелән каплана, бу куныкметаллны суыткач та бетми.* Химия. *Төнбоекларның ялтыравыклы шома яфраклары балавыз сыман куныкбелән капланганнар.* Робинзон әзл.

КУНЫЛУ *ф. з-сыз.* Кунарга туры килү. *Бүген ач кунылды.* М. Гафури.

КУНЫЧ *и.* 1. Аяк киеменең балтырны каплый торган өлеше. *Кыз, озын кунычлы пимасы белән йомшак карны ерып, күрше йортка чыкты.* Г. Ибраһимов. *Газинур белән Мисбах котелокларын тиз-тиз бушаттылар да, кашыкларын итек кунычына кыстырып, командир янына йөгерделәр.* Г. Әпсәләмов.

2. *сир.* Кул киемнәренең (бияләй һ. б.) беләзек турысы яки беләзектән югарыгы өлеше. *Зиннәт гасабиланып сул кулының перчатка куныч тартып куйды.* Г. Бәширов.

КУНЫЧЛЫ: куныч лы галош (ботинка, туфли) — тубыкка кадәр җитеп торган тирән галош (ботинка һ. б.). *Габделәкбәр хәзрәт көн дә Куныч лы галош кия.* Ш. Галиев.

КУПАЙ *с.* Мактанчык; мактанырга, эреләнергә яратучан. *Үз урманында чупай* [*ябалак төре*] *да купай.* Мәкаль. | *и. мәгъ. Купайның калпагы да калай.* Мәкаль.

КУПАЙЛАНУ *ф.* Масаю, кукраю. *Купайланып йөрү. Купайланып кылану.*

КУПАЙЛЫК *и.* Мактанчыклык; буш куык булу сыйфаты. *Купайлык күрсәту.*

КУПА'ЛЬНИК *и.* Су коенганда кия торган костюм. *Салих --- кызның матур муенына, купальнигы өстеннән әз генә күренеп торган күкрәкләренә карап --- аптырап калды.* Г. Мөхәммәтшин.

КУПА'ЛЬНЯ *и.* Зур су өстендә яки су кырыенда су коену өчен ясалган махсус корылма. *Фатыйма белән Хәтимә купальняда, суга сикереп төшмәкче булып, кулларын югары күтәреп торалар.* Г. Тукай. *Марат белән Шамил исә Фәрит әйткән купальняда — берничә генә озын шома такта белән корып алынган ярым түгәрәк эчендә чыпырдаштылар.* Г. Гобәй.

КУПАЮ *ф. к.* купайлану. *Купайганның коты култык астында.* Мәкаль.

КУПЕ *и.* Пассажир вагоннарында аерым бүлмә. *Пассажирлар һәм җиңелчә багажлар белән тулы купеларның берсендә --- безнең Тәзкирәбез бара.* Ф. Хөсни.

КУПЕЦ *и.* Патша Россиясендә сәүдәгәрнең рәсми атамасы. *Беренче гильдия купецы. Казан купецлары.* □ *Купецның кыйбласы Мәкәрҗә.* Мәкаль. *Элекке вакытта икмәк җыя торган зур купецныкы булган шул сары йортка барып кердек.* М. Гали.

КУПЕЦЛА'РЧА *рәв.* Купецларга охшатып; купецларга хас булганча. *Бер кыз һәм, егерме биш-егерме җиде яшьләрендә булыр, яшь купецларча киенгән бер егет чәй эчеп утыралар иде.* Ф. Әмирхан.

КУПЕЦЛЫК *и.* Купец булу; купец хәле. *Купецлык кәсебе.* □ *Купецлыкка чыккан кеше иң башлап иманын сата, ди.* Мәкаль. || *сир.* Купецларга хас сыйфат (мәсәлән, саранлык һ. б.). *Купецлык күрсәту.*

КУПЛЕТ *и.* 1. Шигырь яки җыр строфасы. — *Газинурның күңелендә яшен тизлеге белән яңадан-яңа куплетлар туа, аннары теленә күчә.* Г. Әпсәләмов.

2. Сатирик яки юмористик характердагы кыска җыр (такмак). *Закир сәхнәгә менеп --- үзе язган куплетларын әйтергә кереште.* Ш. Камал.

КУ'ПОЛ *и.* 1. Ярымшар формасындагы түбә яки кыек гөмбәз.

2. *күч. махс.* Геологик катламның иң биек урыны. [*Иванов:*] *Нефтьнең иң күп урыны, Рәхимә, менә шушы тирәдә булырга тиеш.* [*Рәхимә картага күрсәтә:*] *Юк, купол анда түгел, менә бу калкулыкта.* А. Әхмәт.

КУ'ПОЛЛАУ *ф.* Купол (гөмбәз) ясау, гөмбәз белән бизәү. [*Дачаларның*] *уң яктагысы Византия стиленә тартым, куполлап эшләнгән.* Ш. Камал.

КУПОН *и.* 1. Кыйммәтле кәгазьләрнең билгеле бер хак, кыйммәт (мәсәлән, еллык процент күләме) язылган кисеп алынмалы талоны.

2. Урын номеры күрсәтелмәгән театр билеты.

Купоннар кисү — банкка салынган акчадан килеп торган процентлар исәбенә яшәү. *Буржуазиянең зур күпчелеге шушы кәгазьләрдән килгән доход — купоннар кисү белән яшәүче кешеләргә әверелә.* Политэкономия.

КУПОРОС *и.* Күкерт кислотасы тозларының (бигрәк тә бакырлы тозның) техник атамасы. *Бакыр купоросы. Тимер купоросы.*

КУПТАРУ *ф.* 1. Береккән, ябышкан нәрсәләрне бербереннән яки җирлегеннән аеру. *Урыныннан куптару. Куптарып алу.* □ *Эшчеләрнең --- кайберләре шунда таш куптара.* М. Гафури. [*Бәдерниса карчыкка*] *менә шушы әкрен искән язгы җил дә түбәләрне куптарып ташларга көче җитә торган давыл кебек* [*тоела*]. А. Алиш.

2. Тузан, ком һ. б. ш. ны туздыру, өермәләндерү. *Буран куптару. Өермә куптару.* □ *Башкалар* [*атлар*], *далада чаң* [*тузан*] *куптарып, ала айгыр артыннан киттеләр.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Ызгыш-талаш, шау-шу китереп чыгару. *Бунт куптару. Бәла куптару.* □ *Салахов бер яктан, Иванов икенче яктан давыл куптаралар.* Г. Ибраһимов. *Теге егет тавыш куптармакчы булса да, староста аны җитәкләп чыгарып җибәрде.* М. Гали.

КУПШАК *с.* Ярмаланып күпергән, көпшәк. *Купшак кар. Купшак юл.*

КУПШАКЛАНУ *ф.* 1. Купшакка әверелү. *Калын имән ботаклары кышын кигән ак бүреклән салып атканнар, төшмичә калган кар кисәкләре әреп купшакланганнар.* Ф. Хөсни.

2. *к.* кубалаклану. *Борыны купшакланган, дәү күзле, олырак авызлы малай гына, кулын зурларча артка куеп, аңа* [*пыялачыга*] *карап тора иде.* А. Гыйләҗев.

КУПШУ *ф.* Бераз гына купкалау, купшаклану (2 мәгъ.). *Штукатура купшу.*

КУПШЫ *с.* Матур һәм бизәкле киемнәр кигән; көязләнергә, ыспай киенергә яратучан. — *Менә сезгә тирә-якны шаккатырырлык купшы егет, ыспай никрут.* Г. Ибраһимов. *Зифа буйлы купшы офицер Яшь хатынның сүзен ишетте.* М. Җәлил. || Аеруча матурлап, фасонлап тегелгән (кием-салым турында). *Габделбасыйр сандык өстенә куелган купшы бишмәтен үз янына тартып төшерде.* Ф. Әмирхан. || *и. мәгъ.* Купшы, көяз кеше. *Шушы гади ситсы күлмәгендә дә ул* [*Нәфисә*] *бик күп бизәкле купшылардан һич калыша торган түгел бит.* Г. Бәширов. || *рәв. мәгъ.* Аеруча пөхтә итеп, матурлап, ыспайлап. — *Нәрсә купшы киендең, берәр җиргә барасыңмы әллә?* Ш. Камал. *Бу йорт коймалары --- куе яшел буяу белән, тәрәзә, ишек*

читләре ак буяу белән купшы итеп буялган иде. Ә. Фәйзи.

КУПШЫЛ *и.* Тау чыпчыгысыманнар семьялыгыннан чуар каурыйлы кошчык; *русчасы:* щегол.

КУПШЫЛАНУ *ф.* Купшы булып китү; матурлану, бизәнү. — *Яратса шул көйгә яратыр, - - - аңа ярыйм дып, купшыланмам.* Г. Ибраһимов. — *Ай-яй, бик купшыланган сың, әллә кызлар көтәсеңме?* Р. Ишморат.

КУПШЫЛАУ *ф.* Купшы итү, бизәү. *Хәзрәт эшләпәсен бераз кыңгырайтып, купшылап куйды.* Ф. Әмирхан.

КУПШЫЛЫК *и.* Купшы булу. *Көз җиткәч, үзләренең купшылыкларыннан тартынгандай, каеннар яфрак коялар.* Ш. Хөсәенов. || Көязлек, бизәнергәясанырга яратучанлык. *Чандыр гына кыз, бу чаклы купшылык кайдан килгән диген!* Ф. Хөсни. *Бәк-Бәкич купшылыкны ярата, һәрвакыт аның чәче керпеләпеп кырылган, каш нечкәртелгән.* Х. Кәрим.

КУПЫ *и. диал.* Күбесенчә агачтан кырып эшләнгән тирән тәлинкә, кечерәк табак. *Купың яман булса да, эчендә ашы булсын.* Мәкаль. *Алып килгән чынаякларга һәм купыларга чәй ясалды.* Ә. Фәйзи.

КУР *и. диал.* **1.** Шырпы булмаган заманда ут саклау өчен калдырылган утлы күмер, куз. *Туксандагы карт атаң, челдәй чәче агарып, курдай күзе кызарып, тукылдап утын киссә, шул яман.* Н. Исәнбәт.

2. Камыр башы, ачыткы. *Камыр курына күрә.* Мәкаль.

КУРА I *и.* **1.** Каты сабаклы үлән; вак чыбыклы куак. *Ул алан хәзер кеше биеклеге кура һәм үләннәр белән капланган инде.* Р. Мостафин. || Кипкән сабак, каудар. *Җилләр генә уйнап йөри кырларда, Тик кыштырдый кипкән кура урманда.* Ә. Ерикәй. *Без бер үк чокыр-чакырларда корыган куралар, шайтан таякларын, әрем сабаклары җыеп йөргән бер авыл малайлары.* Г. Галиев.

2. *сир.* Кура җиләге үсемлеге. *Кура һәм карлыган яфракларыннан, ашарга ярардай башка төрле үләннән яшел ботка сыман сыекча пешерде солдат.* Ш. Маннур.

Кура җиләге — 1) куе ал төстәге татлы җиләк бирә торган куак. *Кура җиләге яфрагы.* □ *Бу урманда кура җиләге дә күп булмый.* М. Гали; 2) шул куакның җимеше. *Вакытында өзмәсәң, кура җиләге дә бозыла башлый.* Г. Ибраһимов. **Кура җиләге кебек**— таза һәм матур (гадәттә хатын-кыз турында). — *Кура җиләге кебек үз хатыны бар өстеннән фабком маржалары белән гулять итә, каһәр суккан.* Ш. Камал.

КУРА II *и.* **1.** Ихатаның абзарлар, кетәкләр урнашкан һәм аерым киртәләнеп алынган өлеше. [*Тавык һәм үрдәк*], *бер курада бергә ашап, бергә йөреп, дуслаштылар.* М. Гафури.

2. Балчык белән сыланган читән абзар. *Ат җылы курадан буранга чыгуга тыныч сызланды, башын чайкап, пошкырып куйды.* И. Салахов. *Кайчандыр көтүчеләр яшәгән һәм хәзер җимерелеп беткән куранның бер почмагы беркадәр сакланып калган иде.* Н. Фәттах.

КУРАВЫЧ *и. бор.* Бикәләр артыннан йөрүче хатын-кыз кол. *Ишәккә йөгән орып, качыр булмас, Куравычка тун кидереп, хатын булмас.* Мәкаль. („Хатын" биредә „асылзат хатын-кыз" мәгънәсендә.)

КУРАЗ *и. диал.* **1.** Сугыш этәче; сугышчан, усал этәч. *Курыкканга кураз күренә, барып карасаң, чеби дә юк.* Мәкаль.

2. Тавык сыман кыргый кошларның иркәге. *Көртлек куразы. Суер куразы.*

КУРАЙ *и.* **1.** Көпшәсе кипкән үсемлек сабагы. *Тик җилле көннәрдә генә әрәмә арасында катып калган көпшә курайлары төрле-төрле көй чыгарып, җилгә кушылып җырлыйлар.* Ф. Кәрим.

2. *сир.* Көпшә. *Фонтан күленең уртасында мәрмәр бала фәрештә скульптурасы курай аркылы югары су пошкыртып тора.* Ш. Камал.

3. Гадәттә көпшәле үсемлекләрнең сабагыннан ясала торган тынлы музыка коралы. *Шөгаеп, бер көйне уйнап бетергәч, ике кулы белән кысып тоткан кураен авызыннан чыгарды.* М. Гали. *Кайдадыр ераста кемдер курай тарта. Курай моңнары бөтен Агыйдел буйларына тарала.* Г. Әпсәләмов.

◇ **(Кемнең дә булса) кураена бию** — башка берәүнең күрсәтмәләре, теләге, ихтыяры буенча эш йөртү. *Бөтен авыл аның [Маликның] кураена бии иде бит.* И. Гази.

КУРАЙЧЫ *и.* Курайда уйнаучы музыкант. *Кич иде, тулган ай Яктыртканда тугайны; Кайдадыр курайчы Сыздыра курайны.* М. Сөндекле. *Курайчылар курай уйнамас, Башкорт курайлары булмаса.* Җыр.

КУРАЛЫК *и.* **1.** Кура җиләге (куагы) күпләп үскән урын. *Анжерка тирәсендәге яныкта котырып куралык үскән, аның җиләген җыеп бетерә торган түгел иде ул елны.* Ш. Маннур. *Ян бакчаларындагы куралык чәчәген коя башлау белән [Кадриянең] әбисе: — Урманга барыйм әле, күрсәтим әле үзегезгә куралыкларның иң берәгәйлеләрен, — дип йөри башлады.* Э. Касыймов.

2. *диал.* Вак агачлар үскән урын. *Безнең артта куралык, кисеп алдым дугалык.* Җыр.

КУРАНТ *и.* Уйнап суга торган зур сәгать, гадәттә биек башняларга, манараларга куела. *Кремль курантлары.* □ *Менә шушы курантларга карап Сәгатьләрне тигезлибез без.* Ә. Ерикәй. *Мин радионы тоташтырдым. Инде курантлар уйный башлаган иде.* Г. Әпсәләмов.

КУРА'ТОР *и.* **1.** Шифаханәдә авырулар янында кизүлек, дежурлык итүче студент-медик.

2. *иск.* Билгеле бер уку йортының хезмәтчесе, ярдәмчесе булып хисапланган дәрәҗәле кеше.

КУРАЧ *с. диал.* **1.** Чагыштырмача кечкенә, кыска буйлы. *Үзенең курач, бәләкәй булуын тою аны [Хафизны] гарьләндерде.* С. Шакир. *Электән дә ябык, курач Нурулла озын буйлы, таза бәдәнле хатыны янында көзге чебеш кебек кенә булып калган иде.* А. Гыйләҗев.

2. Гәүдәгә таман килми торган, кыска һәм тар (киемсалым турында). *Курач күлмәк. Курач алъяпкыч.* □ [*Николай Николаевич*] *бәләкәй һәм курач халатны җилкә өстенә генә салып палатага килеп кергәндә, Арслан дусты Атнабайны әлерәк кенә озатып җибәргән иде.* Г. Ахунов.

КУРАЧЛАНУ *ф. диал.* **1.** Бәләкәйләнү, бөрешү, тәбәнәкләнү. *Кечерәеп, курачланып калган Николайны ташлап китә алмады ул [Гәрәй].* А. Гыйләҗев.

2. Кечкенә булып калу, кыскару (кием-салым турында). *Минем өченче елны тектергән теге зәңгәр бишмәт тә кыршылып, курачланып калган иде.* Ш. Маннур.

КУРГАН *и.* **1.** Борынгы халыклар үзләренең үлгән башлыклары, батырлары истәлегенә өеп калдырган ясалма калкулык. *Тирбәлә курганнар халыкның күңлендә, Батырлар йоклыйлар курганнар төбендә.* Ә. Исхак. *Курган инде биек кибәнгә охшаган кара балчык өеме булып күренми, аның өстенә тыгыз, куе булып бүтәкә үләне үскән.* А. Таһиров.

2. Кальга, ныгытма (крепость) дивары, стенасы. *Ялгыз агач урман булмас, ялгыз кирпеч курган булмас.* Мәкаль. *Бохара - - - балчыктан ясалган биек курган белән әйләндереп алынган.* З. Бигиев. || Тигез җирдә көтүдәге терлеккә ышык булсын өчен ясалган балчык стена, кутан, кура. *Ташландык кышлау курганнарыннан төтен күтәрелде. Дала яна башлады.* И. Салахов.

КУРГАШ *и.* Аккургаш һәм каракургашның гомуми, уртак атамасы. *Гарәфи абзый, юлда чәй күп эчелә дип, тишек калай чәйнеген тимерчедән кургаш белән яматып алды.* Г. Әпсәләмов. / *с. мәгъ. Әгәр дә мәгәр мин сиңа базардан тәти әйбәр алып кайтсам, калай әтәчме, кургаш сыбызгымы?* Ә. Фәйзи. || *күч.* Пуля турында. *Маңгаена кургаш тимәсә, Үлми икән егет үлмәсә.* Г. Афзал. *Патша хөкүмәте эшчеләрне кургаш һәм штыклар белән каршы алырга булды.* СССР тарихы.

КУРГАШЛАНУ *ф.* 1. Кургаш кушылу, кургаш кисәге белән авырайтылу. *Менә бервакыт кулыңдагы кургашланган аткы белән ашык солдатлар өстенә җибәрелә.* Ә. Фәйзи.

2. Кургаш төсенә керү. *Басу ягыннан күренгән болытлар кургашланып куера башладылар.* Г. Минский.

КУРГАШЛАУ *ф.* Кургаш белән ямау (мәсәлән, тишелгән савытны); кургаш коеп авырайту (мәсәлән, аткыны).

КУРГАШЛЫ *с.* 1. Кургаш кушылган. *Кургашлы цинк. Кургашлы эретмә.*

2. Кургаш коеп авырайтылган. *Кургашлы аткы.*

КУРГАШЫН *и. к.* кургаш. *Бәшир мулла сыйлый кунак, Алдында кургашын табак.* Г. Сәмитова. *Кыска мылтык атыла каты шартлап, Ерак очмый ләкин кургашын.* З. Нури.

КУРГЫ *и.* Тимерченең металл кыздыра торган махсус учагы, миче. [*Тимерченең*] *чүкече, сандалы бар. Кургысы эшли. Яндырган әйбәт күмере дә бар.* Г. Ибраһимов.

КУ!РИЯ *и.* Буржуаз сайлау системасында сайлаучыларның социаль чыгышы, мөлкәте һ. б. буенча барлыкка килгән сайлау группасы. *Дворяннар куриясе.*

КУРКАК *с.* Куркучан, шүрләүчән, кыю түгел. *Куркак кеше. Куркак куян.* □ *Куркак җаннар артларда качып кала, Башкалар алга таба йөгергәндә.* Г. Камал. *Дөньяда куркак булу — иң зур яман.* М. Гафури. *Безнең колын - - - бик куркак. Бергәрсе катырак кычкырып җибәрсә я шакылдап капка ябылса, дерт итеп сискәнеп китә.* Г. Бәширов. / *и. мәгъ. Батыр бер үлә, куркак көн дә үлә.* Мәкаль. *Куркактан үлем көлә.* Ф. Кәрим.

КУРКАКЛАНУ *ф.* Куркак булып, куркучан булып китү. *Куркакланган карга күләгәгә кунмас.* Мәкаль.

КУРКАКЛА!РЧА *рәв.* Куркакларга хас булганча. *Шәрык мәмләкәте - - - колларча бөгәрләнеп, куркакларча куырылып йоклый.* Ф. Әмирхан.

КУРКАКЛЫК *и.* Куркак булу сыйфаты. *Артык саклык — куркаклык.* Мәкаль. *Мактанып әйтүем түгел, кулымда корал булганда, куркаклыкны белми идем мин.* А. Шамов.

КУРКА-КУРКА *рәв.* Туктаусыз куркып; үтә сак рәвештә. *Курка-курка гына безнең янга якынлашкан күк күлмәкле малай - - - кире борылды һәм ук җитезлеге белән күздән югалды.* М. Әмир. *Хикаянең бу бүлеген мин Исмәгыйльгә курка-курка гына укыдым.* Г. Гали.

КУРКАЧ *с.* Курку белдереп торган; курыккан кыяфәттәге. *Кап-кара бөдрә йонлы, бик юаш куркач күзле бу бәтигә мин күрү белән гашыйк булдым.* Ф. Әмирхан.

КУРКУ I *ф.* 1. Хәвеф-хәтәр алдында көчсезлек, ярдәмсезлек тойгысына бирелү. *Күңел курку. Куркып качу. Куркып уяну.* □ *— Хуҗам, нәрсәдән болай курыктың син? — дип сораган әт.* А. Алиш. *Гөлбану куркып агарынды, егыла язып, җиңгәсенә тотынды.* Г. Ибраһимов. || Хәвеф-хәтәрдән яки берәр кыенлыктан качарга омтылу, качу, шүрләү. *Бүредән курыккан урманга йөрмәс.* Мәкаль. *— Курыкмагыз, безнең әби генә ул, — диде Фәрит.* Г. Гобәй. *— Курыкма, курыкма, җаным, авырттырмыйм, — диде Газинур һәм атның авыру аягын бөгеп тезенә куйды.* Г. Әпсәләмов. || Хәвефләнү, борчылу, шикләнү. *— Икебез дә бу дөньяны күйсак, углыбыз Габдулла мәхдүм кем кулында калыр дип бик куркабыз.* Ә. Фәйзи. *— Алып кайткан бүләкне кире алып китәргә туры килмәсен дип курка башладым.* К. Тинчурин. || *Боерык ф. форм.* **курыкма.** „Бу эшнең бер начар ягы (сәбәбе) бардыр" мәгънәсендә әйтелә. *Патша тәхетне ташламас иде дә бит, курыкма, теге якстан кысканнардыр.* Х. Кәрим.

2. Билгеле бер шартларга чыдамау (үсемлекләр һ. б. турында). *Чәчәк кыраудан курка, кыз — алдаудан.* Мәкаль.

3. *ритор.* Кечкенә кыенлыкны яки тискәре хисне сылтау итеп, зур мөмкинлектән баш тарту турында. *Баеп китеп [Бикбулат карт] кулак булмагае дип куркасыңмы?* Г. Бәширов. *— Акча күбәеп китсә, кесәмне тишәр дип куркасыңмыни?* И. Гази.

◇ **Куркыр күлмәк тузган** — һич кенә дә курыкмауны аңлата. *— Харислардан куркыр күлмәк күптән тузган инде.* Сов. әд.

КУРКУ II *и.* Аерым тәгъбирләр составында: куркыну тойгысы. *Куркуга калу. Куркуга төшү. Курку салу.* □ *Сафураның ансыз да телгәләнеп беткән йөрәген шом катыш курку алды.* Г. Ибраһимов.

КУРКУЛЫ *с.* Курку катыш, курку төсмере булган. [*Антанасның*] *башында „нишләргә?" дигән куркулы, борчулы сорау йөри иде.* А. Шамов.

КУРКУЛЫК *и.* Куркудан яки курку тудырган авырулардан дәва итеп кургаштан коела торган кот. *Әле былтыр гына бер хатын, төнлә ындырдан кайтышлый, каберлек өстендә ак нәрсә күреп, акылдан шашкан иде. Куркулык коеп, бер чиләк сөт эчертеп, көчкә төзәткәннәр, ди. Куркулыгы кәҗә төсле булып чыккан, ди.* К. Нәҗми.

КУРКУСЫЗ *с.* Курыкмый торган, йөрәкле. *Арыслан кебек куркусыз егетләрне Үз итсә дә кызым, урынлы.* М. Җәлил.

КУРКЫЛЫК *и. диал.* Бакчага, басуга төшә торган кош-кортны куркыту өчен кеше сурәтендә ясалган сын, бакча карачкысы. *Дәртсез баш карга куркылыгына ярый.* Мәкаль. *Карчык бераздан аны [тарыны] утый башлый, бераз баш күтәрү белән, үрдәк-каз тимәсен дип, кечкенә малайлар төсле итеп куркылыклар куя.* Г. Ибраһимов.

КУРКЫН *и. диал. к.* курку II. *Яңгыр гөжләве, күк күкрәве ишетелә башлады. Бу аны [Садыйкны] бигрәк тә куркынга салды.* Ак юл.

КУРКЫНКЫРАУ *ф.* Курка төшү, курыккан сыман булу. *Карасам, бу бичара хәерче кыз: — Абзый, бер тин бир әле, — ди, куркынкырап.* М. Гафури.

КУРКЫНУ *ф.* 1. Билгесез сәбәптән курку, шомлану. *Куркынып, күзләремне бакчаның түренә аттым да мин ишеккә таба киттем.* Ф. Әмирхан. *Теге хатын, куркынган шикелле, урынныннан тиз генә торды.* М. Гали.

2. Курку тәэсиренә бирелү. *Куркынып башны түбән салу үлемнән сакламас.* М. Гафури. *Вәсилә миңа үпкәли, үзе, куркынган кош кебек, бөрешеп калган.* Ф. Хөсни.

КУРКЫНЫЧ *с.* 1. Хәвефле, хәтәр; үлем яки бәлаказа белән янап торган. *Тыштагы куркыныч бураннның тынгысыз шау-шуы бүлмәне дер селкетә.* Ф. Әмирхан. *Куркыныч хәлләргә очраган чакларда мин - - - уйлап утыруымны белмим.* М. Җәлил. / *рәв. мәгъ. Куркыныч дөбердәп күк күкрәде.* Г. Гобәй.

2. *и. мәгъ.* Хәвефле вакыт, хәтәр тирәлек яки авыр ситуация, авыр нәтиҗәләргә китерү ихтималы булган шартлар. *Куркынычта тору.* □ *Әй, егетләр, тимер куллы ирләр, Зур куркыныч кичерә илебез.* Ф. Кәрим.

Авылда, кайда гына барсаң да, кемне генә курсәң дә, һәммәсе --- ачлык куркынычыннан зарланалар иде. М. Гали.

3. *хәб. функ.* Хәвефләндерә, куркыта. *Кәрарга куркыныч. Уйлавы куркыныч.* □ *Куркыныч иде, ләкин кызлар шүрләмәделәр.* Г. Әпсәләмов. *Төн караңгы, куркыныч, һәр як кабер төсле тыныч.* Һ. Такташ. *Намуслы кеше өчен үлем түгел, тарихка начар исем белән кереп калу куркыныч.* Г. Гобәй.

КУРКЫНЫЧЛАНУ *ф.* Куркынычка әверелү, куркыныч булып китү. *Йөрәктәге салкынлык һәм сызлану артканнан-арта вә куркынычланганнан-куркынычлана бара.* Ф. Әмирхан. *Хәбәрләр тагы да зураеп, тагы да куркынычланып, тиз арада икенче очка барып җиттеләр.* Г. Ибраһимов.

КУРКЫНЫЧЛЫ *с.* Хәтәр, курку хисе тудыра торган, куркытырлык. *Куркынычлы күренеш.* □ *— Куркынычлы сүзләр сөйлисең, Җәләлетдин.* Ш. Камал. *Кайвакытта шаулый ошбу урман, Куркынычлы тавыш чыгарып.* М. Гафури. || Хәвефле, зарарлы. *Нуруллин Васяның бер атака вакытында иңбашы яраланганын сөйләп бирде, ярасының куркынычлы түгел икәнен әйтте.* А. Шамов.

КУРКЫНЫЧЛЫК *и.* Куркыныч булу хәле. *Бакча яңадан үзенең серле куркынычлыгына батты.* Ф. Әмирхан. *Гадәттә бу командировкалар зур куркынычлыклар белән бәйләнгән.* М. Җәлил.

КУРКЫНЫЧЛЫЛЫК *и.* Куркынычлы булу хәле; куркынычлык.

КУРКЫНЫЧСЫЗ *с.* Хәвеф-хәтәрсез, хәвеф-хәтәр көтелми торган. *Доктор [Төхфәтнең] авыртуы куркынычлы дип тә, куркынычсыз дип тә ачык әйтмәгән.* Ш. Камал. *Ул урын, чокыр-чакырлы һәм чытырманлы булса да, куркынычсызрак.* А. Шамов.

КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫК *и. к.* иминлек 1. *Куркынычсызлык советы.*

КУРКЫНЫШУ *ф. к.* куркышу. *Күрәм, ертык болыт кисәкләре Куркынышып читкә китәләр.* М. Гафури.

КУРКЫТКЫЧ *и. диал. к.* куркылык. *Бакчага куркытқыч кую.* || *с. мәгъ.* Куркыта, өркетә торган. *Куркытқыч тавыш.*

КУРКЫТУ *ф.* **1.** Берәр эш-хәрәкәт яки җәза белән янап, курку халәтенә китерү. *— Юк! Юк! Фәхерниса юри мине куркытыр өчен генә әйткән, юри мине сынар өчен генә язган!* Г. Камал. *Урядникның акырынуы мине ике тиенлек тә куркытмый.* Ф. Хөсни.

2. Өркетеп куу, качыру. *Балыкны куркыту.* □ *Куяннарны мин, я кычкырып, я сызгырып, куркытып кына җибәрә идем.* А. Шамов. *Кәҗә бәтиләрен куркытып, җиңел автомобиль үтеп китте.* Г. Әпсәләмов.

КУРКЫШ *и. иск.* Курку, курыкканлык. *Соңгы бомба булып, Куркышыннан [Гитлерның] Таш йөрәге шартлап ярылыр.* М. Җәлил.

КУРКЫШУ *ф.* Барысы бергә, берьюлы курку. *Халык, лачыннан качкан чәүкә көтүе кебек, куркышып читкә таралды.* Г. Ибраһимов. *Илсөяр белән Бикмуш бабай куркышып уяндылар.* Г. Гобәй.

КУРЛЫЙК *аваз иярт.* Торналар кычкырган авазны белдерә. *Өчпочмак булып күккә кадалган торналар отряды „курлыйк! курлыйк!" дип, туган-үскән яклары белән саубуллашып, җылы якларга юл тотканнар иде.* И. Гази.

КУРЛЫК *с.* Курга калдырылган. *Курлык камыр.*

КУРНОС *с. сөйл.* Кыска һәм җәенке (борын турында). *Алма исе иң элек аның курнос борынына бәреп кергән.* Ф. Хөсни. *Минем курнос танау Сафураны Мөдир итеп күйган булалар.* Г. Афзал.

КУРОК *и.* Аты коралларында бәрмә механизмнарның пружинасын ычкындыру өчен хезмәт итә торган кечкенә рычаг. *Миша курок тартып өлгергәнче, Маузер бөркн сары төтенен.* Ф. Кәрим. *Сәлим хәзер шүрләп кенә атлады, мылтыгын алга төзәп, бармагын курокка куеп, ялт-ялт каранып торды.* Г. Гобәй.

КУРОРТ *и.* Һавасы, сулары һ. б. шифалы чаралары булган дәвалау учреждениеләре урнашкан урын. *Врачлар аңа курортка барырга киңәш бирәләр икән.* Ә. Еники. *Гали абзыйга, курортка путевка килеп җиткәнче, колхозга кайтып, бераз хәл җыярга киңәш иткәннәр.* Г. Әпсәләмов.

КУРПЫ *и.* Бер кат чабып алганнан соң үскән яшь үлән; сабагы киселгән үсемлекнең төбеннән шытып чыга торган яшь үсентеләр. *Быелгы җәй шактый явымлы булганлыктан, курпы шундый куе булып, күпереп үсеп киткән.* М. Шәрифуллин. *Ат җибәрдем курпыга, Курпы башын кыркырга.* Җыр.

КУРС I *и.* **1.** Юлсыз йөри торган транспорт чараларының (кораб, самолет), шулай ук юлсыз йөрүче кешеләрнең (сәяхәтче, альпинист) хәрәкәт юнәлеше. *Курс тоту.* □ *Бу мәктәп кешене яңа курс белән алга таба баручы тормыш корабленең капитаны итеп танырга өйрәтте.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Юнәлеш, омтылыш. *Шулай да бу әсәрдә без образлар өстендә реалистик метод белән эшләүгә курс күбрәк булганын күрәбез.* М. Җәлил.

3. *махс.* Кайбер кыйммәтле кәгазьләрнең (акча һ. б.) әйләнештәге хакы, бәясе. *Доллар курсы. Сум курсы.* □ *1923 елда акча курсы искиткеч тизлек белән түбән төгәри иде.* А. Шамов.

КУРС II *и.* **1.** Уку, өйрәнү, дәвалану кебек вакытлы шөгыльләрнең тәмамланган бер циклы, күләме. *Дәвалану курсы.* □ *[Байбәтчәләр] мәдрәсәдә курс тутыра, укый „Йосыф китапларын".* Ш. Мөхәммәдев. *—Сиңа русчаны, немецчаны яхшы белергә дә, аннан соң бухгалтерия курсын үтеп, миңа ярдәмче булырга.* Ф. Әмирхан.

2. Чагыштырмача кыска сроклы уку йорты. *Кичке курслар. Комбайнчылар курсы.* □ *Старков юк иде, аның кече лейтенантлар курсына җибәрелгәнлеген әйттеләр.* Г. Әпсәләмов. *Инженер-техник кадрларның белемен күтәрү буенча институт каршында бер еллык курслар оештырыла икән.* Р. Ишморат.

3. Берәр фәнни дисциплинаның систематик эчтәлеге; шул дисциплина (фән тармагы) буенча дәреслек. *Лекцияләр курсы. СССР тарихының кыскача курсы.*

4. Күпьеллык махсус яки югары уку йортларында укуның бер еллык баскычы. *Ул вакытта Хәйдәр институтның өченче курсында укый иде.* Г. Бәширов.

КУРСАНТ *и* **1.** Курс II (2 мәгъ.) укучысы. *Мин педкурсларны эзләп киттем. Шул ук көнне курсантлар яши торган тулай торактан урын да бирделәр.* Ш. Маннур.

2. Хәрби училище укучысы. *Курсантның вакыты аз, лагерьга, маневрга китәр чак җитеп килә иде.* Г. Ибраһимов.

КУРСИВ *и.* Кулъязма хәрефләренә охшаш авыш шрифт.

КУРСИ!СТКА *и.* Патша Россиясендә югары хатын-кыз курсларында укучы. *Шәрык клубында --- студентларны, курсистка һәм укучы яшьләрне күрәсең.* И. Рәмиев.

КУРСО!ВКА. *и.* Курортта дәвалану һәм туклану хокукы биреп, яшәү урыны белән санаторийдан читтә тәэмин итә торган документ, путевка.

КУРСТАШ *и.* Кем белән дә булса бер курста укыган кеше. | *с. мәгъ. Фазыл исемле курсташ дусты аны [Варисны] бер искиткеч җиргә чакырды.* М. Хәсәнов.

КУРТ *аваз. иярт.* **1.** Бераз кытырдаулы, шыгырдаулы өзек-өзек авазларны белдерә. *Курт итү. Курт та курт.* □ *Ул [Якуп], яшьләрчә курт-курт атлап, ишек алдыннан урамга чыгып китте.* И. Гази.

2. *рәв. мәгъ.* Кытырдаулы, шыгырдаулы өзек-өзек авазлар чыгарып. *Гармоньчы курт кына уйнаган җиреннән „Тәфтиләү"гә күчә.* Ф. Хөсни.

КУРТАЖ *и. иск.* Арадашчыга, маклерга бирелә торган әҗер. *Маклерлар, алучы белән сатучыны килештереп куртаж алу өчен, кулыннан килгәнчә, ялган сөйләүдән дә курыкмыйлар иде.* Ш. Мөхәммәдев.

КУ'РТКА *и.* Ябык изүле кыска өске кием. *Мех куртка.* □ *Һидият солдат сукносыннан тегелгән курткасының төймәләрен ычкындырып җибәрде.* Ш. Камал.

КУРЧАК *и.* 1. Бала-чага (гадәттә кыз балалар) уйнар өчен күбесенчә нәни бала сурәтендә ясала торган сын. *Бакчы, уенын башлаган [кыз], күңелен биргән курчагына.* Дәрдмәнд. || Курчак театрындагы персонаж фигура. *Болар һәркайсы — курчаклар яхут маскалар театрындагы марионеткалар.* М. Җәлил.

2. *күч.* Үз мөстәкыйльлеге булмаган, башкалар кушуы буенча эш йөртә торган шәхес яки группа. *Мөртәт Гыйбай, сатлык җан—кулаклар курчагы.* Г. Толымбай. *Бер ише кешеләр, җан саклауны, хәвефхәтәрсез яшәүне бөек идеаллар хакына дигән сылтау белән аклап, ихтыярсыз курчакка, обывательгә әверелде.* Ә. Еники.

3. Бөҗәкләрнең личинкалык чорын тәмамлап, җитлеккән корт булганчыга кадәр үсеш стадиясе—аларның махсус тышча, сүрү белән капланып, хәрәкәтсез яту дәвере. *—Сез бит күбәләк булганчы башта үзегез көя булгансыз, яфрак ашап симереп курчакка әйләнәсез, аннан гына күбәләк төсенә керәсез.* А. Алиш.

4. *с. мәгъ. күч.* Кечкенә һәм пөхтә. *Бу курчак бүлмәгә аяк басуым белән үк өстемдәге киемнең керлелеген, аягымдагы итегемнең тузанлылыгын сизеп алдым.* А. Шамов.

Курчак театры—сәхнәдә җанлы артистлар түгел, фигуралар—курчакларны хәрәкәтләндереп уйнала торган театраль тамаша. *Мин кече яшьтән үк курчак театрларын яратып карый идем.* Г. Камал. **Курчак уены**—1) курчакларны кешеләр, хайваннар һ. б. кебек йөртеп, сөйләштереп уйнала торган уен; 2) *күч.* җитди булмаган яки бик җиңел эш. *Баласыз көн—курчак уены, Бала тугач була кыены.* Мәкаль. **Курчак уйнау** —курчак уены уйнау. *—Әй мин Сабир абый туенда курчак уйнап йөридер идем әле.* К. Тинчурин.

◊ **Курчак кебек**—курчак уенындагы кебек матур һәм пөхтә. *Ак өйне курчак кебек җыештырып, Карлыгач-сылу керергә чакыру өчен килә.* Г. Ибраһимов. *Бетерде укып егет һәм бурильщик булды кышка. Өсбаш курчак кебек.* Ш. Маннур. **Курчак режим** — курчак хөкүмәт урнаштырган режим. *Чомбеның курчак режимы белән баш күтәрүчеләр беркайчан да килешмәячәкләр.* Тат. яшь. **Курчак хөкүмәт** — илнең үз халкы тарафыннан түгел, ят көчләр тарафыннан власть башына куелып, шулар күрсәтмәсен үти торган хөкүмәт. **Курчак өе кебек**—кечкенә һәм пөхтә өй яки бүлмә турында. *Туй уңае беләндер инде, сипләп яңартылган мунча курчак өе кебек иде.* Ә. Еники.

КУРЧАК-КУРЧАК: курчак-курчак уйнау—1) курчакларны уйнатып, мавыгып утыру; 2) *күч.* җитди булмаган эш белән шөгыльләнү; җитди карамау. *Егет кыздан биһуш - - -, ә кыз исә башкалар белән чуалып, егет белән курчак-курчак уйный.* А. Расих.

КУРЧАКЛАНУ *ф.* Курчакка (3 мәгъ.) әверелү (бөҗәкләр турында). *Курчаклану стадиясе.*

КУРЧАКЛЫ *и.* Курчаклар белән уйнала торган уен, курчак уены. *Курчаклы уйнау.*

КУРЧАКЛЫК *и.* 1. Курчак (2 мәгъ.) булу (хәле). *Кызыкма курчаклыкка, төкер мещан кануннарына.* М. Максуд. || Эчтәлексез булу. *Мин каһкаһә белән көләм шунда, Мескенлеген күреп кешенең, Ул табынган потлар — курчаклыгын, Фанилеген дөнья эшенең.* Н. Арсланов.

2. Ясалмалылык, үзенне җансыз курчак кебек тоту. *Ләкин бу әсәрне уйнаганда да байтак кына артистлар „җанлы газетчылык", „курчаклык" традицияләренә бирелеләр.* М. Җәлил.

КУРЫЛДАУ *ф.* Тавык затыннан булган кошларның характерлы озын бер аваз чыгарулары турында. *Бакча буенда, төрле якка сибелгән чебиләрен җыя алмыйча, кабарынып, чуар тавык курылдап йөри.* Г. Бәширов.

КУРЫН *и.* Бер кеше балык тота торган кечкенә җылым.

КУРЫПСА *и. диал.* Яшь юкә агачыннан суелган юкә. *Чабатачы дптеринең - - - өе тулы юкә-курыпса.* С. Хәким.

КУРЫС *и.* Каезланмаган, юкәсе суелмаган кабык. *Бабайлар җәй көннәрендә курыс төшереп тамак ялгый торган булганнар.* М. Әмир. [*Госман агай*] *бервакыт, ботинкасының олтаны кубып төшкәч, курыстан ничек әйбәт итеп олтан әмәлләвен дә бәйнәбәйнә сөйли.* Р. Төхфәтуллин.

КУРЬЕ'Р *и.* 1. Эш кагәзьләрен илтеп, хәбәр тапшырып йөрүче хезмәткәр. *Завод конторасы курьеры.* □ *Заһидуллин, тиз генә курьерны чакырып, өеннән шофер Дәмин Хәйбрахмановны табып китерергә кушты.* Ф. Хөсни.

2. Ашыгыч язулар, йомышлар белән зур аралар үтеп йөрүче хезмәткәр. *Дипломатик курьер.* □ *Кавалер бу ведомствоның төрле шәһәрләр арасында йөри торган курьеры гына.* Ф. Әмирхан.

КУРҖЫН *и.* Ат, ишәк һ. б. аркасына салып йөртү өчен җайланган, авызлары белән бер-берсенә каратылып тоташтырылган ике зур кесәдән гыйбарәт капчык. *Сәет ат аркасына салынган ике яклы йон капчык—курҗынны акрын гына алып өем янына китерде.* И. Салахов.

КУСАР *и. диал.* Зур пычак, чыра пычагы. *Кусар белән юну.*

КУСАРЛАП *рәв. диал.* Кусар белән кырып. [*Рәүфә*] *көзге былчырак катканөйалдын кусарлап кыра-кыра гәрәбә төсле саргайтты.* А. Шамов.

КУСТ *и.* Аерым группалар яки аерым оешмалар берләшмәсе; вакытлы группа. *Педсоветта, куст методик берләшмәсендә иркенләп тәнкыйть итәр өчен аерым бер категория укытучылар була.* М. Мәһдиев.

КУСТАРЬ *и.* Үз кораллары белән еш кына үз өендә (алачыгында) эшләүче вак һөнәрче. *Ул йорттаШырдан авылыннан килеп бүрек эшләүче Низами исемле бер кустарь фатир тора иде.* М. Гали.

КУСТАРЬЧЫЛЫК *и.* 1. Кустарьлар эше. *Губернатор, гадәттән тыш сәләт күрсәткән берничә якут малаен берәр төрле кустарьчылык мастерскоена урнаштырыгыз, дип җавап биргән.* СССР тарихы.

2. *күч.* Начар оештырылган һәм техника белән начар коралландырылган яки артык гади ысул белән алып барыла торган житештерү. || Иҗади эштә гади һөнәр методларын куллану. *Партиябез - - - иҗатта формалистик трюклыкка, төссезлеккә һәм кустарьчылыкка каршы.* Сов. әд.

КУТАН *и.* Казахстанда һәм Себердә: ябусыз, түбәсез зур абзар. *Кутандагы киртәләрдә иллегә якын мал бәйләнеп тора.* Г. Ибраһимов.

КУТЫР *и.* Тире авырулары яки эренле яра өстендә барлыкка килгән, өсте касмакланып каткан чуан яки яра. *Ходайбирденең башына, өч-дүрт урында кутыр булып, канаганга күрә, кәгазь ябыштырылган.* М. Гафури. *Тәненә, битенә чыккан кызгылт-карасу кутырлар малайның ябык гәүдәсен ямьсез күрсәтәләр.* С. Шакир.

КУТЫРЛАНУ *ф.* 1. *к.* кутырлау. *Хайван итеп урмәтерләр алар* [*фашистлар*], *Кутырланып бетәр тезләрең.* Ф. Кәрим.

2. Кутырга әверелү. *Яра өсте кутырлану.*

КУТЫРЛАУ *ф.* Кутыр чыгу, кутыр белән капланы. *Утка төкермә, иренең кутырлар.* Мәкаль. *Кутырлап, йоннары коелып беткән өрәкне* [*кәҗәне*] *кем алсын?!* К. Нәҗми. || Кайрылану, мүкләнү (агачташ турында). *Марат — башы күкләргә җитеп үскән, ак көүсәсе әле әз генә дә кутырламаган каенга кутәрелеп карады.* Г. Гобәй. *Маһирәнең күзе, ияләшә төшкәч, иң элек ямь-яшел мүк үсеп кутырлаган таш стеналар арасында почмакка поскан улы һадига төште.* А. Гыйләҗев.

КУТЫРЛЫ *с.* Кутырлаган, кутырлар белән капланган. *Үгезе үлгән курада кутырлы кәҗә баш булыр.* Мәкаль.

КУУ *ф.* 1. Билгеле бер урыннан китәргә мәҗбүр итү. *Ку кәҗәне бакчадан яманлык белән.* Дәрдмәнд. || Сөрү, еракка җибәрү, читләштерү. *Өйдән куып чыгару.* □ *Без дошманны илдән куып, Оясын көл итми торып Өйгә кайтачак түгел.* М. Җәлил. *Ат урынына сезне эшләттеләр, Эт урынына сезне кудылар.* Ә. Ерикәй. *Бәбкәләрең чыккач чип-чип дип, --- Без куарбыз сезне „кит, кит!“ дип.* Ш. Бабич. || Тарату. *Җыенны куу. Демонстрацияне куу.*

2. Качучы, йөгерүчене эзәрлекләп, артыннан калмыйча килү. *Равиль кача, --- аны куып тоталар.* А. Әхмәт. *Күселәр аны* [*песи баласын*] *куа-куа алҗытып бетергәннәр.* А. Алиш. || Качарга мәҗбүр итү һәм артыннан эзәрлекләп бару. *Дошманны үз оясына кадәр куу.* □ *Кызыл частьлар, партизан отрядлары ак банданы кысыклап куып киләләр.* Г. Гобәй.

3. Алдарак баручының артыннан җитәр өчен тизлекне арттыру, алдагылар белән тәнгәлләшергә омтылу. *Данилов кызу-кызу атлап взводын куып китте.* Г. Бәширов. || *күч.* Үсешең, камилләшүең һ. б. сыйфатларың буенча алда булганнар белән тиңләшергә тырышу. *Безнең бригадага тагын берничә кеше арттырсак, без аларны* [*башка бригаданы*] *куып җитеп, узып китәчәкбез.* М. Гали.

4. Билгеле бер юнәлештә барырга мәҗбүр итү, әйдәү. *Терлекне көтүгә куу.* □ *Кунарбай монда куйлар куып алып килгән.* Ә. Фәйзи. || Җигелгән терлекне тиз барырга, чабарга мәҗбүр итеп кычкыру, сугу һ. б. *Ку әле тизрәк атыңны!* Ф. Әмирхан. || *күч.* Транспорт машиналарын тиз йөртү турында. *Нишләргә?! Әгәр тракторны актык чигенә кадәр кусаң?* Г. Бәширов.

5. *тар.* Ятларның терлеген үз ягына алып кайту. *Юныс карт --- көтү-көтү малларны ничек урлап, куып алып киткәнен сөйләде.* Г. Ибраһимов.

6. Берәр тоташ массаны (сыеклыкны, томанны һ. б.) билгеле юнәлештә һәм тиз хәрәкәтләндерү. *Җилне төтен кумый, җил төтенне куа.* Мәкаль. || *тех.* Сыеклык яки газны торбалар буйлап басым ярдәмендә күчерү. *Бензинны насос белән бакка куу.* □ *Кызыл кирпечтән түгәрәкләп салынган манара — су куу башнясы.* И. Салахов.

7. Сыек яки каты матдәне кыздыру ярдәмендә таркатып, берәр кирәкле сыеклыкны яки газны аерып алу. *Агачны корылай куу.*

8. Билгеле бер эштән, посттан һ. б. китәргә мәҗбүр итү, дәрәҗәдән төшерү. — *Эшче булдың исә, менә куалар, кугач, кайда эш табармын икән дип, куркып торырга кирәк була.* Г. Коләхметов. || Коллективтан читләштерү. *Карак мулланы авылдан куарга дип тау хәтле тамгалар җыелды.* Г. Ибраһимов.

9. *күч.* Дәвам итү. *Азчылык һаман иске гадәтләрен куудан узып китә алмаган.* Ф. Әмирхан. || Берәр эшне, процессны бик кызу һәм шул ук вакытта бик үк намуслы булмаган төстә алып бару; эшнең бер ягы белән генә мавыгу турында. *Табыш куу. Эш куу.* □ *Сүз куган балага юлыгыр, йомыш куган казнага юлыгыр.* Мәкаль. *Котылса, --- Галиулла дөнья артыннан да бу кадәр кумас иде.* И. Гази. *Сан артыннан гына кума, сыйфат турында да кайгырт!* Р. Ишморат.

10. *күч.* Түгәрәк саннар белән белдерелгән билгеле бер яшькә якынлашу турында. *Алтмышны куу.* □ *Мөстәкыйм карт яшь ягыннан тугызынчы унны куса да, болай күрер күзгә таза иде әле.* М. Әмир.

КУУ'ЗИКУ *и.* Гәрәнкәнең терлек азыгы өчен үстерелә торган сорты. *Терлек азыгы гәрәнкәсе куузику— мул уңыш бирә торган кыйммәтле тамыразык.* Соц. Тат.

КУХА'РКА *и. иск.* 1. Хосусый йортта аш-су эшләрен башкарырга ялланган хатын-кыз. *Капка алдында дворник Илья белән шул йортта үк торган зәңгәр күзлекле чиновникның кухаркасы көлешеп-көлешеп әллә ни сөйли иделәр.* Ш. Камал.

2. Гомумән ашчы, пешекче хатын-кыз (түбән квалификацияле хатын-кыз мисалы буларак та әйтелә). *Без һәрбер кара эшченең һәм һәрбер кухарканың дәүләтне идарә итү эшенә хәзер үк керешергә сәләтле түгеллеген беләбез.* В. И. Ленин.

КУ'ХНЯ *и.* Аш-су хәзерләү өчен махсус бүлмә яки өй. *Газизә абыстай кухняга аш өлгертергә чыгып китте.* Ф. Әмирхан. || Кырда аш-су пешерү өчен махсус җайланма. *Ур астында бер-берсенә капма-каршы туктатылган ике вагон. Алдарак күчмә кухня.* И. Салахов.

КУ'ЧЕР *и.* 1. Кешеләр йөртә торган җигүле ат белән идарә итүче хезмәткәр. *Кучер, утырган урыннан җитез төшеп, колоколларны җибәрде дә, яңадан килеп утырып, атларга китәргә әмер бирде.* Ф. Әмирхан. *Арба кузласына утырган кучерның кулында кушучка да сыймаслык күп тармаклы дилбегә.* Ш. Маннур. | *с. мәгъ.* — *Минем бер кучер егетем бар, шуны чакырыйкмы әллә, патша хәзрәтләре?* Әкият.

2. Тарантасның алгы ягында ат тотучы өчен утыргыч, кузла. *Абзыкай кучерга бер иске сырма сапты. Мин, алгы тәгәрмәчкә басып, кучерга менеп утырдым.* Ә. Еники. *Кара айгырның дилбегәсен ныкытеп тотып, ике кулын алга сузган килеш кучерда утырган егеткә Гали абзый сөйкемле караш ташлады.* Г. Әпсәләмов.

КУ'ЧЕРЛЫК *и.* 1. Кучер эше. [*Мансур*] *кар көри, утын яра, ат карый, кучерлык хезмәтен дә үти.* А. Расих.

2. *сир.* Экипажда кучер утыра торган махсус урын. *Әнә теге баһадир чанага утырды, әнә Зариф та кучерлыкка сикереп менде.* Г. Ибраһимов.

КУЧКАР I *и.* 1. *иск.* Янып торган чыраны яткырып яки кыстырып кую өчен махсус җайланма (гадәттә тәкә яки болан мөгезеннән эшләнгән).

2. Мич кашагасы өстендә лампа һәм вак-төяк савыт-саба куяр өчен махсус киштә сыман итеп ясалган мәйданчык. *Хәдичә --- лампаның өстәлдә утыруын нигәдер килештермичә, аннан алып, кучкарга илтеп куйды.* Г. Бәширов. [*Миччә*] *кучкарны да искесе шикелле гади итеп түгел, ә нәфис итеп, сырлап эшләгән иде.* А. Шамов.

КУЧКАР II *и.* 1. Печтерелмәгән сарык тәкәсе; өер тәкәсе. *Һәр мөгезле—кучкар түгел, Һәр канатлы —шоңкар түгел.* Мәкаль. *Күршенең кузысы кучкар чаклы.* Мәкаль. *Шәрифҗан, кучкар мөгезе төсле*

мыекларын тагын да бөтерә төшеп, усал җавап кайтарды. К. Нәҗми.

2. *бор.* Шәхси сакчы. *Дустыңны коткар, ул сиңа булыр кучкар.* Мәкаль.

КУЧКЫЛ *с.* Карасу, каралҗым. *Кучкыл төтеннәрнең бөдрә толымын Кояш нуры килеп сөядер.* Ш. Маннур. *Бодайлар куе булып, кучкыл яшел булып, егетләр мыегыдай сызылып кына чыгып килә.* Ә. Еники. | *и. мәгъ. Егетнең йөзенә бер төрле сөйкемле кучкыл йөгергән.* Ф. Хөсни.

КУЧКЫЛЛАНУ *ф.* Кучкыл төскә керү. *Кучкылланып кара болыт йөри, Күк келтери, кыя тау тетри.* Ш. Маннур.

КУЧКЫЛЛЫ *с.* Аз гына каралҗымланып күренгән. *Кучкыллы нурлар. Кучкыллы йөз.*

КУЧТЫ *и. диал.* Дус, әшнә (гадәттә үзеннән кечерәкләргә карата әйтелә). — *Шәп, кучты, шәп! Килә чәктә синнән полный Отелло чыгар.* И. Рәмиев.

КУШ I *с.* Ике, икесе бергә булган; икесе бер төптән үсеп чыккан. *Урманда куш тирәк, дөньяда дус кирәк.* Мәкаль. *Ялан җирдә үсә, ай, куш каен, яфраклары җилгә тирбәлә.* Җыр. || Икесе бер бөтен тәшкил иткән, икесе бер бөтен булган; ике бердәй кисәктән, предметтан торган. *Уртасына төтен һәм пар чыгарып бара торган зур самовар утыртылган куш көймә диңгездә йөзеп бара торган кораб сыман акрын гына --- йөзә.* Ә. Фәйзи.

Куш (булып) күренү — ике булып күренү, караганда икегә аерылып күренү. *Курыкканга куш күренә.* Әйтем. **Куш итү**—арттыру, күп итү. *Данлыклы көрәш бара --- бөек халыкның Бәхетен куш итү өчен.* Ә. Ерикәй. **Кушияк**—икегә аерылып торганияк. *Булат трест управляющие Зозуляның чаларып бетә язган күперенке зур мыегына, куш иякле мөлаем йөзенә төбәлеп, сүзсез генә утырды.* Г. Ахунов. **Куш йолдыз** *астр.* — бер-беренә тартылу аркасында үзләренең уртак авырлык үзәге тирәсендә әйләнеп йөргән ике йолдыз. *Кайбер очракларда куш йолдызның орбита яссылыгы безгә кырын торганлыктан бер йолдыз периодик рәвештә икенчесен каплый.* Астрономия. **Куш-куш булып** — икешәр-икешәр булып, парлашып. *Балалар куш-куш булып читкә китәләр, үзләренә яшерен исемнәр кушып, узаманнар янына киләләр.* Н. Исәнбәт. **Куш сүзләр** *лингв.* — тезү бәйләнеше нигезендә ике сүздән ясалган кушма сүзләрнең төре. **Куш тырнаклар** *иск.* — *к.* куш җәяләр. **Куш өй** — капиталь стена белән (мәсәлән, бүрәнә стена белән) икегә бүленгән авыл өе; алтыпочмаклы өй. *Күбесе биш стеналы куш өйләр, түбәләре такта, калай, шифер белән ябылган.* Ф. Хөсни. **Куш җәяләр** — персонаж сүзләрен, цитаталарны, туры сөйләмне һәм шулай ук әсәрләрнең, китап-журналларның һ. б. ш. исемнәрен аерып күрсәтү өчен кабул ителгән билге: „ “ яки « » (сүзнең күчмә, шартлы мәгънәсен аңлату өчен дә кулланыла). *Туры сөйләм автор сөйләме белән бергә бер үк абзацта килгәндә, ул куш җәяләр эченә алына.* К. Сабиров.

◇ **Куш бугаз** *гади с.* — бер дә юкка күп һәм кыскырып сөйләүче кеше. — *Акыртмагыз шул куш бугазны, авызын каплагыз.* М. Шабай. **Куш йөрәкле** — кыю, курыкмас, батыр. [*Сөләйман:*] *Бәхетле, озын гомерле балалар булсыннар, бабалары кебек --- куш йөрәкле булсыннар.* Г. Әпсәләмов. **Куш куллап** — шатланып, бик теләп, зур теләк белән. *Куш куллап каршы алу.*

КУШ II *и. сөйл.* (рус теленнән кергән сүз). Күп акча, зур сумма. *Шактый гына куш эләктергән.*

КУШАВАЗ *и. диал.* Жанры ягыннан бәетләргә якын торган фольклор әсәре.

КУШАК *и. диал., иск.* Киң иңле озын тукыма кисәгеннән ясалган билбау, пута. *Ул, чын извозчик кебек, башына кучер бүреге, өстенә кызыл кушаклы тун кигән.* А. Расих. *Тальянский кушак син буасың, Әллә нинди матур буласың.* Җыр.

КУШАМ: кушам ат — төп атка ярдәм итү өчен перәшкәгә (янга) җигелгән ат.

КУШАМАТ *и.* Кешедән көлеп, мәзәк өчен яки конспирация максатларын күздә тотып бирелгән икенче исем. *Менә бүген иртә инде фамилиясен, кушаматын да хәбәр иткәннәр: Гәрәй белән янәшә камерада Зоя Горбатова дигән бер большевик кыз зинданда утыра икән.* Г. Ибраһимов. *Ә ул егет булып үскәндә, „Күркә Нәгыйм“ дигән кушамат аңа бик нык ябышкан иде.* Ш. Камал.

КУШАНУ *ф. иск.* Тагу, асу. *Аембикә --- кылыч кушанган, бүректән.* Н. Исәнбәт.

КУШАРЛАП *рәв. диал.* Берничә кеше бергә, берничә кеше бергә кушылып. *Зәйнәп күршедәге иптәш кызлары белән, кушарлап, моңлы татар көйләреннән „Ашказар“, „Баламишкин“ вә башкаларны җырлыйлар иде.* М. Гафури.

КУШАРУ *ф. иск., диал.* Икесен бергә китерү, икесен бергә кую (кулларны, аякларны һ. б.). *Куян, арт аякларына утырып, ал тәпиләрен кушарып калды.* А. Тимергалин.

КУШАЯК *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан далада һәм чүлдә яшәүче, сикереп йөри торган зур булмаган хайван. [*Далада*] *кушаяклар һәм башка ваграк кимерүчеләр очрый.* География.

КУШАЯКЛАП *рәв.* Арткы һәм алгы аякларны бердәм алга табан ташлап (чабу турында). *Алаша кушаяклап чабып китте.* Р. Төхфәтуллин.

КУШАЯКЛАТЫП, КУШАЯКЛАНДЫРЫП *рәв.* Арткы һәм алгы аякларны бердән алга табан ташлатып (атка карата әйтелә). [*Шәрифҗан*] *бер каравында атын кушаяклатып чабып килүче разведка башлыгы Гыйльметдинне күрде.* И. Гази. *Кушаякландырып сикертеп чабып барганда, кыз ат өстендә һаман шулай уңайсыз утыра.* А. Шамов.

КУШБАРМАК *и.* Бер-берсенә кушылып үскән ике бармак. [*Ярулла:*] *Хәзер без синең белән кушбармак кебек икәүдән-икәү.* Ф. Бурнаш.

КУШБАШ *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан төче суда яши торган киң башлы балык. *Буага уйнап кына кармак салырга төшкән кеше дә өч-дүрт куырырлык чабакларны, кушбашларны алып кайта иде.* А. Гыйләҗев.

КУШЕ'ТКА *и.* Аркасы булмаган, ләкин бер як башы яту өчен беркадәр калку итеп ясалган диванчык. *Мохтар белән Габдулла, тәмәке тартып, кушеткада утыра иделәр.* Ш. Камал.

КУШКАНАТЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Бөҗәкләр отрядының исеме, бу отрядка чебеннәр, черкиләр, кигәвеннәр һ. б. керә.

КУШКОЛАК *с. сөйл.* Ике зур колаклы, ике зур колагы булган. *Куян да баласын „кушколак пәһләван“ дип йөртәдер, ди.* Әйтем.

КУШКЫ *и. иск., диал.* Күп җәпле, күп очлы камчы. *Хәлфә — камчы вә кушкылар илә балаларның сыртларын яручы.* Г. Тукай. *Карт хәзрәт кушкы тотып, безнең каршыда тилергәндә, — „Николай патша төшкән“, — диделәр.* Г. Газиз.

КУШКӨБӘК *и. сөйл.* Ике көпшәле ау мылтыгы. *Һаман кушкөбәккә кызыгып карап торуыбызны күреп, [малай] елмайды.* Г. Мөхәммәтшин.

КУШКӨБӘКЛЕ *с.* Ике көпшәле, ике көбәкле.

КУШЛАВЫК *и. сөйл.* Куыш урын, куышланып торган урын. *Чокырда, юлның аскы ягында, язгы кар-*

суы ашаган кушлавык. Габиш төн үткәрер өчен шул кушлавыкка кереп посты. Ф. Кәрим.

КУШЛАНУ *ф.* Икегә әйләнү, ике булып күренү. [*Хәбир*] *Томан эчендә бик сәер булып җәелә, кушлана башлаган кешеләргә карап уйланып утырды.* Ш. Хөсәенов.

КУШЛАУ *ф.* Бергә китереп кую, янәшә китереп кую (күбрәк учлар турында). [*Нәҗип:*] *Ике кулымны кушлап тотып, баш бармакларымны авызыма кабып, пароход тавышы белән кычкыртып җибәрдем.* Ф. Әмирхан.

КУШЛАШУ *ф.* Икесе бер төркем хасил итү, икесе бергә булу турында. *Шул рәвешчә малайлар, кушлашып, узаманнар каршына килеп кушаматларын әйтеп, ике лагерьга бүленеп чыгалар.* Н. Исәнбәт.

КУШМА I *с.* 1. Берничә предмет яки матдә кушылып ясалган. *Кушма азык.*

2. Берләшкән, бергә кушылган. *Кушма штатлар.*

3. *лингв.* Ике яки берничә тамыр сүздән торган, ике яки берничә тамыр сүз берләшкән. *Кушма исемнәр. Кушма фигыльләр.* □ *Кушма сүзләр ике яки берничә сүздән кушылып ясалалар һәм яңа бер мәгънә белдерәләр.* Тат. теле грамм. || Ике яки берничә җөмләдән торган, ике яки берничә җөмләне эченә алган. *Татар телендәге кушма җөмлә төзелешен фәнни планда тикшерү совет чорында көчәйде.* В. Хангилдин.

КУШМА II *и. диал.* 1. Буй тактачыклардан ясалган агач савыт, агач чиләк. *Стена буена тезеп куелган агач кушмаларның өстенә әрекмән яфрагы бөркәп, такта һәм кирпеч бастырып куелган иде.* Г. Ахунов.

2. Сал агызганда үзенә бер бөтен итеп беркетелгән агачлар рәте. — *Салда биш кушма, кушма саен икешәр кеше җитә.* Х. Сарьян.

КУШМАЛЫК: кушмалык итү — җырлаучыга яисә музыка коралында уйнаучыга кушылып уйнау, аккомпанементлык итү. *Хөснетдин скрипкада --- кушмалык итә иде.* Ш. Камал.

КУШМЕТАЛЛАР *и. күпл. махс.* Катлаулары төрле металлардан торган пластинкалар, чыбыклар, эшләнмәләр һәм ярымфабрикатлар.

КУШОРЛЫК *и. сөйл.* Бодайның үзенә бер махсус төре, борай.

КУШСУЗЫК *и. лингв.* Ике сузыкның бер иҗек хасил итеп берләшкән кушылмасы; *к.* дифтонг.

КУШТАН *с.* 1. Ялагай, тәлинкә тотучы. *Куштан шәкертләрнең берсе аның озын таягын кадерләп кулыннан алып китте.* М. Гафури. *Аның атасы куштанрак кына мишәр карты, --- ахырдан риза булып җибәрде.* Ф. Әмирхан. | *и. мәгъ. Сүзе үтмәгән аңа куштанның.* Ш. Маннур.

2. Хатын-кызлар турында: ирләргә яраргa тырышучы, артык төче мөгамәләле; кыланчык. *Нәсимә, борын очы чак кына күтәрелеп тору белән бергә, кararга чибәр һәм куштан да иде.* Ш. Камал.

3. *и. иск. күпл.* Революциягә кадәр татар авылларында власть вәкилләре белән арадашлык итүче һәм, ярлы крестьяннарның интересларын яклаган булып, чынында байлар, кулаклар интересын яклаучы кешеләр. *Кайчандыр Байтирәк куштаннары, землемерга бер тәпән бал белән ике сарык ришвәт биреп, Аланбашның Яурышкан иңкелен үзләренә кистереп алганнар.* Г. Бәширов. [*Бай*] *хәйләсез надан халыкны ышандырып, авылдагы бер-ике куштанны сыйлап, бер-ике кадак чәй биреп, кулга алгач, алтыннан кыйммәтле урманнарын, җир-суларын, дисәтинәсен гомерлеккә бер-ике тәңкәгә алып, бичара башкортларны бөтенләй ялангач калдыр[а] --- торган иде.* Ш. Мөхәммәдев. || *и. иск.* Октябрь революциясеннән соң колхозлаштыру чорына кадәр „кулак яклы", „кулак иярчене", „кулак җырын җырлаучы" мәгънәсендә кулланыла. [*Гани:*] *Бәлки, мине ат койрыгына таккан куштаннар, тиреләрен алмаштырып, әле дә шыпырт кына яталадыр анда.* Г. Әпсәләмов. *Кулак куштаннарын йомычкадай Көрәш ярына илтеп суктылар.* М. Җәлил.

Куштан итәк — бәби итәк. [*Чуваш хатынының*] *күк киндер күлмәгенең итәк очларына төрле төстәге тар куштан итәкләр белән суташлар, тасмалар тотылган иде.* З. Бәшири.

КУШТАНЛАНУ *ф.* 1. Ялагайлану, ялагайлык күрсәтү, тәлинкә тоту. *Үзләренең халыклары алдында куштанлану өчен, буржуазия тешен кыса-кыса безгә дуслык кулларын сузарга мәҗбүр.* И. Гази.

2. Чытлыклану, төчеләнү, ялагайлану, яраргa тырышу (хатын-кызлар турында). *Унтугызынчы елда* [*Александра Сигизмундовна*] *ирен коткару өчен, Салахиев белән куштанланып йөргән, диләр.* Г. Ибраһимов.

КУШТАНЛЫК *и.* 1. Куштан (1, 2, 3 мәгъ.) булу, ялагайлык, юмакайлык, тәлинкә тоту. *Юма тел белән куштанлык аны кеше итте, ул аны* [*Сәйфетдинне*] *маңгай тирен агызмыйча гына бал-май эчендә йөздерде.* Г. Бәширов. *Мәҗди байның даны китмеш куштанлыктан, байлыктан.* Бәет.

2. Чытлыклык, яраргa тырышу; түбәнчелекле булу. [*Бай*] *сөя үзе сагынганны, куштанлыкны, һаман үзенчә булганны.* Г. Тукай. [*Гыйрфан бай кызы*] *иркәләнде, күзләрендә элекке заманның нуры, куштанлыгы ялтырап китте.* Г. Ибраһимов.

КУШТОЯКЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Куш бармаклары (аеры тояклары) икесе дә бертигез үсеш алган имезүче хайваннар отрядының атамасы (мәсәлән, дуңгыз, сыер, бегемот).

КУШТЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* кушу 1.

2. *сөйл.* Кемгә дә булса исем бирү, кемгә дә булса исем кушу. *Малайларның иң кечесенә әнвәр дип исем куштырган.* Ш. Камал. [*Иштуган:*] *Без менә шулай уйлашкан идек: берсен Илдус, икенчесенә Илгиз куштырыйк.* Г. Әпсәләмов.

КУШУ I *ф.* 1. Нинди дә булса ике яки берничә төрле предметны, матдәне бергә катнаштыру, аралаштыру. [*Хәйретдин:*] *Тегермәннән карабодай белән солыны бергә кушып тарттырып кайтканмын.* Ф. Бурнаш. [*Көлне*] *туфрак белән куштылар да болынның Шәйхаттар бабай сайлап куйган җирләренә илтеп сиптеләр.* Г. Гобәй. || Нинди дә булса сыеклыкларны бергә катнаштыру.— *Зәйни абый сиңа кызыл белән ак аракыны ике бутылкасын гына кушарга әйткән иде ич, ә син барысын кушкансың.* Ф. Бурнаш. — *Сыраларына нәрсә булса да усал нәрсә кушканнар булса кирәк, эчкәч кәеф килеп китә.* Ф. Хөсни. || Ике яки берничә предметны бер бөтен итеп берләштерү, алардан бер бөтен ясау. *Мәдинәнең ике җәймәсеннән кушып тегелгән театр пәрдәсе тагын ачылды.* К. Нәҗми. *Бәхет өчен бергә кушыйк Күңелләр омтылышын.* Г. Хуҗи.

2. Нинди дә булса башка бер нәрсәгә өстәү; өстәп бирү. *Сиңа дигән күлмәклек яныма җиде чирекле француз яулык та кушармын.* А. Шамов. || Җитмәгәнне җиткерү өчен өстәү (акча һ. б. турында). *Бу одеялны ул Казанга килгән елында өеннән алып килгән зур юрганын саткан акча янына ике сум кушып алган иде.* Ф. Әмирхан.

3. Әйтелгәнгә яки язылганга һ. б. ш. үзеннән өстәү, өстәп җибәрү. — *Агай әйткәннәрне кушып, шул кәгазьдә язылганнарга ризамы, — дидем.* М. Гали. *Бу дәмәди — бик күп сөйләүче һәм йөзгә җитмеш*

биш процент ялган кушып сөйләүче Галиәкбәр агайның --- приказчигыдыр. Ш. Мөхәммәдев.

4. Нинди дә булса кешеләр төркеменә яңа кешеләр китереп өстәү, катнаштыру. *Тагы берничә балтачы белән ташчыны куштылар да, иген-тару җыелып бетүгә эшкә тотындылар.* Г. Ибраһимов.

5. *күч. сөйл.* Кавыштыру, өйләндерү. [*Хәй:*] *Дөньясын гөл итәрбез, егет белән кызны кушып.* М. Фәйзи.

6. *мат.* Ике яки берничә санга кергән берәмлекләрне берләштерү, аларның суммасын табу. *Саннарны кушу.* || *и. мәгъ.* Ике яки берничә санга кергән берәмлекләрнең суммасын берләштерүдән гыйбарәт булган арифметик гамәл. *Кушу кагыйдәсе.* □ *Кушу нәтиҗәсе һәрвакыт төгәл бер сан белән аңлатыла.* Арифметика.

7. *биол.* Төрле төргә караган үсемлекләрнең, хайваннарның ана женесен ата женесе белән аталандыру. *Башка төрле сортлар һәм токымнарны кушудан алынган кушылдыкларда еш кына искиткеч үзгәрүчәнлек һәм барлык билгеләрнең төрлелеге ачыла.* Биология.

Кушу билгесе — плюс (+) билгесе (саннарны кушканда яки унай зурлыкны белдергәндә кулланыла). *Кушу билгесе --- кушылучылар арасына куела.* Арифметика.

КУШУ II *ф.* **1.** Кемгә дә булса берәр эшне эшләргә, башкарырга әмер бирү, боеру; тәкъдим итү. *Командующий иптәш Фрунзе безгә җәяүләп диңгез кичәргә кушты, без кичтек.* Г. Бәширов. *Газинур, урынбасары сержант Комлевка алгы кырыйны җентекләп күзәтеп торырга кушып, взвод командиры янына йөгереп китте.* Г. Әпсәләмов. || Берәр төрле эш йөкләү. *Дни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды.* Г. Тукай. *Аңа бүшка хезмәтләр дә кушалар.* М. Гафури. || Күрсәтү, билгеләү. *Хакны бай кушкан таксадан ким бирмәсәләр, аның белән китә, ким бирсәләр тагын урынында кала.* М. Гали. || *и. мәгъ.* Боерык, әмер, тәкъдим. *Рәиснең кушуы буенча, Гайшә иренең гомерендәге актык көннәрен, актык сәгатьләрен сөйләде.* Г. Ибраһимов.

2. Таләп итү. — *Без үзебездән килмәдек, закон куша бит, — диделәр.* Г. Тукай.

3. Берәр нәрсә эшләргә хокук бирү, рөхсәт бирү. [*Нургали:*] *Дәүләт законының кушуыннан тыш, андый башбаштаклыкны эшләргә ярамый.* Т. Гыйззәт.

4. *сөйл.* Ашарга бирү (хайванга), ашарга кую. *Атларны ашарга кушу.* □ *Без атны кертеп, туарып ашарга кушкан арада, шактый яктырды.* М. Гали.

Кушып ялгау *махс.* — ялгам ботагын ана үсемлектән аерып алмыйча, бары якынайтып кына чыбыкча ялгау; аблактировка.

КУШУ III *ф.* Кемгә дә булса исем бирү, исем кую, исем билгеләү. [*Әсма:*] *Ир булсын да сиңа охшасын иде, без аңар „Тимербулат" дип ат кушар идек.* Г. Ибраһимов.

КУШУЧ *и.* Озынча түгәрәк савыт рәвешендә янәшә куелган ике уч. *Рабига җиңги, кушучына таяныпп, ак самоварына текәлгән хәлдә, квартирант кызы турында әнә шулай бераз гына зар түгеп алды.* Э. Касыймов. || Шулай куелган ике учка алынырга мөмкин булган яки алынган сибелүчән, чәчелүчән әйбернең микъдары. *Ул арада Айсылу почмак яктан бер кушуч чикләвек алып чыкты.* Г. Бәширов.

КУШУЧЛАП *рәв.* **1.** Кушуч белән, кушучка алып. [*Сөмәя:*] *Кушучлап су алып шопырдатып юына башлады.* А. Гыйләҗев.

2. *күч. сөйл.* Күпләп. *Диңгез лачыны кебек кушучлап чын әҗәләр таба алмаса да, базарга бер генә мыскал да дулкын күбеге илтмәгән,* Р. Төхфәтуллин.

КУШЪЯКТЫЛЫ *с.* Биналар турында: ике яктан яктылык кергән, ягъни бер-беренә каршы ясалган яки берсе икенчесе өстенә урнашкан тәрәзәләре булган. *Кәримовларның ике катлы, кушъяктылы китап һәм галантерея кибетен --- шушы оста салдырган.* И. Рәмиев.

КУШЪЯУЛЫК *и.* Ике кат итеп ябына алырлык зур яулык; бөркәнчек. *Сабир, юк мәшәкать дип, бөркәнчек (кушъяулык) ябындырмый.* Г. Ибраһимов.

КУШЫЛГАК *и.* Төрле токым хайваннар, яисә төрле төрдәге үсемлекләр кушылудан килеп чыккан тума яки үсемлек; гибрид. *Илебезнең күп кенә районнарында заанен токымлы кәҗәләр белән җирле кәҗәләр кушылгаклары таралган.* Йорт эшләре.

КУШЫЛДЫК I *и.* Башка елгага килеп кушыла, коя торган елга. *Кама — Волганың күшылдыгы.* □ *Көнчыгыш славяннар --- Днепр белән аның кушылдыклары буйларында --- яшәгәннәр.* СССР тарихы.

КУШЫЛДЫК II *и. к.* кушылгак. *Башка төрле сортлар һәм токымнарны кушудан алынган кушылдыкларда еш кына искиткеч үзгәрүчәнлек һәм барлык билгеләрнең төрлелеге ачыла.* Биология.

КУШЫЛДЫРУ *ф. к.* кушу I (7 мәгъ.). *Ул вакытта инде Мичуринның гибридлаштыру буенча тәҗрибәсе була, һәм ул үсемлекләрне кушылдыру буенча үзенең оригиналь методларын куллана.* Биология.

КУШЫЛМА *и.* **1.** Нәрсәләрне дә булса механик рәвештә аралаштырганда, кушканда яки берәр нәрсә механик рәвештә кушылганда барлыкка килгән катнашма. *Комбикормнар, төрле азыкларның кушылмасыннан гыйбарәт булып, гадәттә махсус заводларда ясалалар.* Зоология.

2. *махс.* Молекуласы ике яки берничә элемент атомнарыннан торган матдә. *Химик кушылмалар.* □ *Углерод водород белән, метаннан тыш, тагын бик күп кушылмалар барлыкка китерә.* Химия.

Кушылма азык — терлекләргә ашату өчен кулланыла торган, тиешле дәрәҗәдә тукландыру матдәләре, минераль тозлары, витаминнары булган төрле азыклардан гыйбарәт катнашма. *Хуҗалыкларда еш кына кушылма азыклар (комбикормнар) кулланалар.* Зоология.

КУШЫЛМАУЧЫЛЫК *и. махс.* Нәрсәнең дә булса башка нәрсә белән кушыла алмавы. *Мичурин төрле төрләргә кергән затларның кушылмаучылыкларын җиңү ысулларын эшләде.* Биология.

КУШЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к. кушу* I (1, 3, 4 мәгъ.).

2. Нинди дә булса ике яки берничә предмет аралашу, катышу. *Ялкын белән, металл белән кушылган җир бу.* Г. Хуҗи. *Ишекне ачуга Шәмсинең борынына махорка төтене кушылган парлы җылы килеп бәрелде.* Г. Бәширов. || Ялгану, тоташу. *Свисток тавышына паровозның кискен, кыю тавышы кушылды.* К. Нәҗми. || Берләшү, күмәкләшү. *Әллә күп хуҗалык бергә кушылып, сөрәсезме җирне берләшеп.* М. Гафури.

3. Берәр кешегә яки кешеләр төркеменә килеп катнашу. *Фазыл мең азап белән башкортларга килеп кушыла.* Г. Ибраһимов. [*Булатның*] *җитәкчелеге астында халык, баш күтәреп, алпавыт усадьбасын тар-мар итеп, Пугачев явына кушылырга китә.* М. Җәлил.

4. Өйләнешү, кавышу. — *Нәтиҗәдә кыз, без аның белән кушылганда бәхетле гаилә тормышы кора алмабыз һәм җәмгыятебез өчен дә файдалы кешеләр була алмабыз, дигән фикергә килә.* Р. Ишморат.

5. Нинди дә булса фикергә, тәкъдимгә риза булу, ризалык белдерү; килешү. [*Гаяз:*] *Аның тәкъдименә*

барлык ярлылар гына түгел, авылның төп катлавы — урта хәллеләр дә кушылырга тиеш. М. Әмир. *— Мин дә Каюм абыйның фикеренә кушылам.* Ш. Камал. || *сөйл.* Уртаклашу, теләктәшлек итү. [*Сөләйман:*] *Сәгыйдә, мин сезнең кайгыгызга кушылам.* Һ. Такташ.

6. Сүзгә, җырга, уенга һ. б. ш. эш-хәрәкәткә катнашу. *Җыен читендәрәк басып торган яшьләр дә бәхәскә кушылдылар.* А. Шамов. *Рәхим, гитарага кушылып, бераз карынкы, шулай да ишетер өчен матур тавыш белән җырлый башлый.* Ф. Әмирхан. *Әлеге ялгыз өргән эткә авылның башка этләре дә кушылып өергә тотындылар.* Г. Минский.

7. Башка елгага кою, башка елгага агып килеп керү, тоташу. *Бу елга уникә чакрым киткәч, Өршәккә, Өршәк Димгә кушыла.* Г. Ибраһимов. *Шул арада Зөя елгасы Иделгә кушылган җирдәге борылыштан агып килә торган бер сал күренде.* М. Гали.

8. *сөйл.* Үзеннән алда килгән исем белдергән хәлгә килүне аңлата. *Дус кушылдылар Арыслан берлә бер көн Юлбарыс.* Г. Тукай. *Шул көннән алар аерылмас дуслар булып кушылдылар.* Г. Бәширов.

9. *махс.* Реакциягә кереп, бер бөтен барлыкка китерү, берләшү (матдәләр турында). *Май селте ярдәмендә су белән кушыла ала.*

КУШЫЛУЧЫ *и. мат.* Арифметик гамәлдә башка сан (зурлык) белән кушыла торган сан (зурлык). *Кушылучыларның тәртибен алыштырудан сумма үзгәрми.* Алгебра.

КУШЫМ *и. сөйл. к.* кушымта 2. *— Болай матур җырлый, моңланып җырлый, нәкъ әзеннән бара... Бакчы, кушымны ничек сузып тибрәндереп китә.* Э. Касыймов.

КУШЫМТА *и.* 1. Нәрсәгә дә булса кушып бирелгән яки бирелә торган нәрсә, өстәмә. *Редакция, билгеле, андый шигырьләрне аерым җыйнап, җурналга кушымта рәвештә әдәби җыентыклар бирү юлын практикага кертер.* М. Җәлил. || Гомумән, өстәмә булып торган яки саналган сыйфатлар, үзлекләр. *Куе кара чәчләр арасыннан күренә торган җиңелчә генә алсурак ак муен, урта гына, ләкин бик беленерлек калкып тора торган күкрәк, --- тулырак кына, ләкин арыклыктан ерак түгел кулчыклар — көзгедән күренгән матур йөзнең гүзәл кушымталары иде.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Өстәмә, өстәп бирелә торган. *— Менә сез бу гражданинга водокачка бирергә дип, резолюция салгансыз, ә ул тагын ниндидер кушымта әйберләр бирүне сорый.* Ш. Камал.

2. *махс.* Җырда, шигырьләрдә һ. б. ш. һәр куплеттан соң кабатлана торган строфа. *Җырның кушымтасына Хәмзә дә кушыла вә азакка кадәр җырлый.* М. Фәйзи. *Кушымтаны да икәү бергә җырладылар.* Г. Әпсәләмов.

КУШЫМЧА *и. лингв.* Телдә аерым кулланылмыйча, сүзнең тамырына яки нигезенә ялганып килә торган кисәкчек, морфема. *Төрләндергеч кушымча. Сүз ясагыч кушымча.*

КУШЫМЫК *и. диал. к.* кушымта 2. *Абыстай бәет әйтә башлый, кызлар кушымык әйтәләр.* Н. Исәнбәт.

КУШЫРУ *ф.* 1. Кулларны янәшә китереп кую, берсе өстенә икенчесен китереп кую. *Ул кулларын кушырып күкрәгенә кысты.* А. Шамов. *Сабира, кулларын күкрәгенә кушырып, бер Кадершага, бер Рәхиләгә серле итеп карый.* И. Туктар. || Күкрәк каршысына китереп кулларның учларын бер-берсенә тидерү (кайбер халыкларда сәламләү билгесе буларак кулланыла). *Берничәсе, үзенең яшерен эшләгән пычраклыгының матбугатка фаш булу ихтималыннан куркып, миңа ерактан кул кушырып сәлам бирә торган булдылар.* Г. Ибраһимов.

2. Аякларны бергә китереп берсе өстенә икенчесен чалыштырып салу. *Фазылҗан абзый яңадан аяклары белән булышырга тотына: бер бөгә, тагын суза, кушырып карый.* Р. Төхфәтуллин.

КУЫК *и.* 1. Сыеклыкта барлыкка килеп, басым нәтиҗәсендә аерылып чыга торган, һава яки берәр төрле газ тулган үтә күренмәле шар. *Кичке кояшның тәрәзә аша төшкән кыйгач нурлары аның тир бөрчекләре белән ялтыраган битен, аллы-гөлле сабын куыклары ябышкан бармакларын эреп баручы бакыр төсенә кертеп яктырталар.* К. Нәҗми. || Тән пешкәндә, кабарганда тиредә барлыкка килә торган сулы кабарчык.

2. *анат.* Кайбер тереклек ияләре эчендәге һава яки сыеклык тулган кечкенә капчыкчык, сүре. *Балык куыгы. Үт куыгы.* □ *Җиденче ротадагы румыннар, сыер куыгыннан ясалган сорнайларны кычкыртып, сәяк кастаньеткалар шакылдатып, гажәп төзек тавышлы оркестр оештырдылар.* Ш. Усманов.

3. Дәвалау максаты белән тәнне җылыту яки салкынайту өчен кайнар су яисә боз тутырыла торган резин капчык. *Җәрәхәт тирәсендәге урыннарга боз салган куык куялар.* Анатомия.

4. Лампаның пыяладан ясалган торбасы, лампа пыяласы. *Каюм тиз генә бишле лампаны рәтләп ут кабызып җибәрде һәм ватылып төшкән башына калай әйләндереп утырткан куыкны лампага кигезде.* Ә. Фәйзи. *Гарәфи --- өстәл янына килеп, өстәлдәге лампаның куыгына өрде.* Г. Әпсәләмов.

5. *этн.* Суелган казның яки үрдәкнең үңәченнән, я булмаса хайваннарның эчәгеннән ясалып, эченә һава өреп тутырылган озынча шар. *Гыймазов зәңгәр төсләргә буялып тәрәзә өсләренә эленгән каз куыкларына карап алды.* С. Рафиков.

6. *күч. сөйл.* Ялган; күпертеп әйтелгән сүз (хәбәр). *„Баш ташлап" эчү турында никадәр күпертелгән булса, „гулять" итү турындагысына да шул чама ук куык өстәлгәндер.* Р. Төхфәтуллин.

Куык гөмбә — кипкәч эче кара-коңгырт тузанга әйләнә торган шар сыман гөмбә; *русчасы:* дождевик.

◇ **Куыгы шиңү** — 1) хәле бетү, дәрте бетү. *Шулай да аның сер бирәсе килмәде. Бик йөгереп йөргән иде, куыгы тиз шиңде малайның, димәсеннәр.* И. Гази; 2) кәефе бозылу, тәкәбберлек бетү. [*Җиркуп:*] *Әгәр шуны башкарып чыксак, Маликның да куыгы тиз шиңәр.* И. Гази. **Куык очыру** — 1) үзендә булмаган сыйфатлар белән мактану. [*Җәлил*] *һәммә мөгамәләсендә* [*үзен*] *үзендә булган мәртәбәсеннән өстен тота, һәрвакыт бераз кабарырга, куык очырырга маташа.* Г. Ибраһимов; 2) ялганлау, алдау. [*Ярулла:*] *Ай, Сирай, Сирай, куык кына очырасың икән лә, --- син мине алдап егерме тиеннән колак кактыра яздың бит.* М. Фәйзи. *Тормыш өйрәнәм мин. Тиздән бер ел. Чыгып булмый әле очына. Төзүчеләр һаман балчык ташый, Горгаз һаман куык очыра.* С. Баттал.

КУЫКЛАНУ *ф.* Куыклар (1 мәгъ.) барлыкка килү, куыклар белән капланы. *Аның өсте манма су, кулларын пешеп куыкланып беткән.* Г. Әпсәләмов.

КУЫКЛЫ: куыклы үлән *бот.* — яфракларында шарсыман куыклары булган, судагы вак организмнар белән туена торган су үсемлеге (куыклар планктонның кечкенә организмнарын тоту һәм үзләштерү өчен хезмәт итә).

КУЫЛМА *и. махс.* Җылыту яки кайнату юлы белән состав кисәкләргә аерылган матдә.

КУЫЛА-СӨРЕЛӘ *рәв. сөйл.* Кайдан да булса чыгарга яисә читкә китәргә тупас рәвештә мәҗбүр итеп. [*Гыйрфан байлар*], *дөньяның әллә кай җирләреннән куылга-сөрелә кылган кәчаклар кәрванына*

кушылып, бераз агалар. Г. Ибраһимов.

КУЫРДАК *и. сөйл. к.* куырма. *Тәмле куырдак.*

КУЫРМА *и.* Кыздырылган ит.

КУЫРМАЧ *и.* Табада кыздырып ашамлык рәвешендә хәзерләнгән бөртекле ашлык яки борчак.

КУЫРУ *ф.* 1. Азыкның кайбер төрләрен сусыз кыздырып ашамлык рәвешендә хәзерләү. *Фәриха суганлап, борычлап --- бәрәңге котлетлары куыра.* Ш. Камал. [*Әткәй:*] *Барыгыз, --- саргайган җиренән борчак җыеп китерегез --- Мин ут ягып куырырмын.* Г. Ибраһимов.

2. Киптерү, корыштыру. *Башак та чыгарып өлгермәгән арышны кояш куырды.* И. Гази.

3. Эссе һаваның, эссенең тәнгә килеп бәрелүе, тәнне кыздыруы турында әйтелә. *Мунча --- башны куырып алырлык итеп кызу ягылган.* М. Гали. || Шулай ук салкын һаваның, суыкның тәнне чеметеп-чеметеп алуы турында әйтелә. [*Урамга*] *чыгарлар иде дә шул, кыш бабай бик яман куыра.* А. Алиш. || Кайнар яки ачы ашамлыкның авызны, иренне авырттыруы, ачыттыруы турында.

4. *күч. сөйл.* Нәрсә дә булса эшләргә ашыктыру, кемгә дә булса ашыгырга кушу. *„Я сөйлә инде, зарыктырма!“ дип Габдулла иптәшен куыра башлады.* Ә. Фәйзи.

КУЫРЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* куыру 1, 2.

2. Утта кызып ашамлык хәленә килү. *Борчак тиз куырылды, кәләпүшләргә тутырып алдык та арбага биек итеп төялгән яшел печән өстенә атланып утырдык.* Г. Ибраһимов.

3. Бөрешү, корышу; беркадәр кибү. *Вакыты узганлыктан, җир җилләге кояшта бераз куырылган.* М. Гали. *Сулда җил уңаена сөрлеккән солы, кара башын җиргә төрткән тары, саргаеп, куырылып беткән ясмык җирләре җәелеп китте.* И. Гази.

4. *к.* куыру 3. *Иртәнге салкын белән өшеп, куырыла төшкән тәннәр, әллә нинди җылылыкны искә төшергән кебек чымырдап киттеләр.* М. Гафури.

5. Җыерылу, йомарлану, җыерчыклар барлыкка килү (кием, тукымалар турында). *Өстендәге бөтен киеменең бертөрле куырылып, җыерылып торуы сәбәпле, хәзрәтебезнең кыяфәте көлдермәслек түгел иде.* Ф. Әмирхан. || *күч.* Йомарлану, бөгәрләнү. *Гаепләнүче баскан җирендә куырыла төште.* Г. Ибраһимов.

КУЫШ *и.* 1. Нинди дә булса бер предметта булган бушлык, буш урын, куышлык. [*Зөһрә*] *,мич куышыннан тарак алып килеп, карчыкның башын тарый башлый.* А. Әхмәт. || *с. мәгъ.* Эче буш булган. *Сандугачлар шундый чутылдый, шундый яңгыратып сайрыйлар, аларның авазы, гүя, куыш пыяла чикләвекләр сыман чыңгырдап, агачлар өстенә коелып тораладыр шикелле.* Г. Бәширов. *Аның озын табанлы, куыш эчле, җиңел тимераяк аласы килгән иде.* А. Шамов.

2. Агач кәүсәсенең үзагачы черегән урында барлыкка килгән бушлык, тишек. [*Сөләйман:*] *Урманда юкә куышында умарта күче таптым.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Шундый бушлыгы, тишеге булган. *Бакчаның суга караган башындагы эче куыш зур имән дә боларның бөтен дөньядан яшерелгән мөкатдәс серләрен саклый, әманәтләрен тапшыручы хезмәтен кыла иде.* Г. Ибраһимов.

3. Киртәләре таган сыман яисә дүрткел итеп куелып, өсте кәс, кабык, чыбык-чабык, печән, салам һ. б. ш. ябылып ясалган чатыр. [*Умарта бакчасындагы*] *кабыктан ясалган куыш, аның тирәсендәге коры умарталар, читлек, күзлек, тубал кебек нәрсәләргә ияләшеп беткән идек.* М. Гафури. *Бабай да, акрын гына куышына кереп, тоткан балыкларын бөзгә юарга биреп җибәрде.* М. Җәлил.

4. *күч. сөйл.* Өй, йорт-җир, тора торган урын. *Аның яралы күңеле үзенең җылы куышында, тыныч тәрбияле тормышта гына савыгыр кебек иде.* Г. Бәширов.

◇ **Куыш карбыз тибү** — тик йөрү, буш йөрү. *Мондый вакытта куыш карбыз тибеп, физкультуралашып әүмәкләшүгә караганда, үзебезнең колхозның ашлыгын җыйнарга ярдәм итсәк, яхшырак булыр.* Ш. Камал.

КУЫШ-КУЫШ *и. сөйл.* Балалар уены; *к.* куышлы. *Кунак малайлар белән күңелле итеп „куыш-куыш“ уйнадык.* Р. Төхфәтуллин.

КУЫШЛАНДЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* куышлану.

2. Куышлык ясау, куыш итеп ясау. *Сал алар турысына килеп җиткәч, ике учын куышландырып авызына куеп, бик сузып кычкырды: „Кем салы бу? Каян киләсез?“ — дип, Петя аларга кычкырып карады.* М. Гали. *Бервакыт хәзрәт икә йодрыгын куышландырып тотты да, картинаны шулар аркылы карый-карый, җәһәтләп артына чигенә башлады.* Ф. Әмирхан.

КУЫШЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* куышлау.

2. Куышлык барлыкка килү, куышлык ясалу. *Агачның эче куышланган.*

КУЫШЛАУ *ф.* Куышлык ясау, куыш итеп ясау. *Минем килү белән мылтыкны сөяп, капчыкны салып, окоп тирәнәйтергә әчкә таба куышлап керү[ем]не күр[де].* Ә. Таһиров.

КУЫШЛЫ *и.* Уенда катнашучылардан берсенең башкаларны куып тотудан гыйбарәт балалар уены. *Әнә чем-кара күзле, түп-түгәрәк йөзле бер малай бабасы белән куышлы уйный.* Р. Төхфәтуллин.

КУЫШЛЫК I *и.* 1. Берәр предмет эчендәге буш урын, бушлык. *Теш куышлыгы.*

2. *махс.* Тереклек организмында булган бушлык яки төрле эгъзалар урнашкан урын. *Күкрәк куышлыгы.* □ *Ашкайнату каналы авыз куышлыгыннан башлана, бу куышлыкта тел һәм тешләр урнашкан.* Анатомия.

КУЫШУ *ф.* Бер-береңне узарга яки тотарга тырышып йөгерү, чабу; йөгерешү. [*Малайлар*], *бер-берләрен куышып, боз өстендә шуып йөриләр иде.* А. Шамов. *Бу ике дус кочаклашып, берсен-берсе куышып, сикерешеп уйный --- башлаганнар иде.* Г. Тукай. || Атта һ. б. бер-береңне узарга тырышып, ярышып чабу, чабышу. — *Минем белән куышканда аты сөртенде аның.* М. Гали.

КУЮ *ф.* 1. Берәр әйберне нинди дә булса бер урынга, җиргә урнаштыру. *Мәхмүт, Насрыйның кәйләсен алып, учакка кыздырырга куя.* Ш. Камал. [*Карчык:*] *Минем чормада киптерергә куйган борчакларым бар иде.* А. Әхмәт.

2. Нәрсәгә дә булса берәр төрле торыш бирү, нинди дә булса рәвешкә китерү. *Гарифуллалар --- арбаны йөзтүбән куеп, ясаган куышларына кайттылар.* М. Гафури. || Нәрсәне дә булса берәр нәрсәгә янәшә, якын китерү. *Полк командиры биноклен күзенә куйды.* А. Шамов. *Корт башын колакка куеп тыңласаң, анда әллә нинди ерак җил ыжылдавына охшаган тавыш килә.* Ә. Фәйзи.

3. Нинди дә булса позициягә урнаштыру (сугыш, оборона һ. б. ш. өчен). [*Дәүләтшин:*] *Пулеметларны флангларга куйсак, ничек булыр?* И. Гази.

4. Нәрсәне дә булса бер әйбергә, предметка беркетү, беркетеп ясау. *Тәрәзәгә пыяла кую. Күлмәккә яка кую. Звонок кую.* □ *Барысыннан да күбрәк йозак эше була: өстәл, шкаф, сандыкка йозак куярга, яисә ачкычы югалган йозакларны ачарга, яисә укеңче ачкычлар ясарга китерәләр.* Щ. Усманов.

5. *сөйл.* Берәр нәрсәне төзү, кору, ясау. *Өй кую.* □ *Халык сиңа - - - Һәйкәл куйды, Сиңа булган сөю хакына.* Ә. Ерикәй. || Өю, өеп ясау (кибән, эскерт, чүмәлә һ. б. турында). *Эскерт куйганда да, богыл салганда да, каралты түбәләрен япканда да, ул һәрвакыт өстә эшләргә ярата.* Г. Әпсәләмов. *Бабайлар колхозның борчагын, ясмыгын чаптылар, ураклылар артыннан зур-зур кибәннәр куя бардылар.* Г. Бәширов.

6. Берәр җирдә, урында нинди дә булса эш башкарырга билгеләү; берәр хезмәткә билгеләү. *Шул көнне кич Садыйк йортына берничә сакчы куйдылар.* М. Гали. *Берсен, тәҗрибәсе дә бар дигән булып, завхоз иттеләр, икенчесен директор итеп куйдылар.* Г. Гобәй.

7. *сөйл.* Комарлы уеннарда: күпме булса да акчаны банкка кертү, уенга кертү.

8. Берәр нәрсәне ашарга яки эчәргә әзерләгәндә, билгеле бер халәт барлыкка китереп, аны шул халәттә калдыру. *Мин шундук камыр куйдым да Тәнзилгә йөгердем.* Э. Касыймов. [*Миртимер:*] *Син чәй куярсың, мин аш салам.* Т. Гыйззәт.

9. Сәхнәдә берәр төрле тамаша башкару, спектакль күрсәтү. *Пионерлар концертны клубта һәр ике колхоз өчен куярга булдылар.* Г. Гобәй. [*Гаяз:*] *Җәй көне дә бер спектакль куя алырбыз бит әле.* М. Әмир.

10. Язу, язуда күрсәтү. *Имза кую. Мәкаләгә баш кую.* □ [*Җәләл*] *акча сораса җибәртә, ләкин үзе һичбер* [*хат*] *язмый, сәлам куярга да сирәк әйтә.* Г. Ибраһимов. || Язуда тыныш билгеләрен куллану. *Өтер кую.* □ *Шуңа күрә, хөрмәтле укучы, рөхсәт итегез шушы урында нокта куярга.* Ә. Еники.

11. (Бәясен) билгеләү. *Китапка бәя кую.* [*Хөрмәтулла:*] *Бәяләрен бик кыйбат куймаса сорармын.* Т. Гыйззәт.

12. Бәяләү, өстен яки түбән дип табу. *Үзен-үзе зурга куя Кызларның кайсылары.* Җыр. [*Җәләл:*] *Тукайның әҗәе шикелле тезелгән матур шигырьләре белән берәртән куярлык шигырь яза алсаң, шәп булыр иде.* Ш. Камал. || Нинди дә булса билге белән бәяләү, шул билгене язуда күрсәтү. *Рәсем ясалып бетеп, әниләре „5“ не куйгач, Сания белән Марат йокларга яттылар.* Г. Гобәй.

13. Берәр төрле мәсьәлә күтәрү, күтәреп чыгу. *Бу шигырьдә М. Гафуриның милли азатлык мәсьәләсен куйганы күренә.* М. Җәлил. [*Нургали:*] *Идарә алдына мәсьәләне каты куячакмын.* Ә. Еники. || Нинди дә булса бурычлар һ. б. ш. билгеләү, йөкләмәләр алу. *Максат кую. Таләп кую.* □ *Без пьесаларның социализм чоры куйган яңа проблемаларга җавап бирүен күзәтергә тиешбез.* М. Җәлил.

14. Оештыру; урнаштыру (тәртип һ. б. ш. турында). *Бу мәсьәләдә Гөлсем апа үзе куйган тәртиптән кире карыш та чигенми иде.* Г. Гобәй. [*Мирсәет:*] *Эшкә алынгансың, эшлә. Куй тәртип, бетер шапшаклыкны.* Р. Ишморат. [*Шәймәрдән:*] *Мин үземнең хуҗалыкны барысына да үрнәк булырлык итеп куяр идем.* К. Нәҗми. || Алдан билгеләү, ачыклау. *Без - - - капитан куйган сроктан ике сәгать әләк „телләрне“ генералга китереп җиткердек.* Ә. Айдар.

15. Нәрсәне дә булса хәл итәргә тәкъдим итү. [*Рәис:*] *Мәсьәлә җитәрлек аңлашылды дип уйлыйм. Хәзер аны тавышка куям.* Ш. Усманов. || Берәр нәрсәне хәл итүне кешенең үз иркенә калдыру. [*Немец офицеры:*] *Без көчләмибез, без сезнең ихтыярыгызга куябыз.* Ә. Еники. — *Үз иркенә генә куйыйк дисең дә, әгәр ул туйлыгына, мәһәренә нибары ике йөз сум гына биреп куйса?* М. Фәйзи.

16. Нәрсәгә дә булса ирешү, нинди дә булса зур уңыш күрсәтү. *Рекорд кую.*

17. Кайбер кушма сүзләр һәм тезмәләр составында килеп, түбәндәге мәгънәләрне белдерә: 1) „бирү“ фигыленең мәгънәсенә туры килә. *Күңел кую. Исем кую. Юл кую;* 2) билгеле бер физик көч куллану, хезмәт сарыф итүне белдерә. *Көч кую.* □ *М. Гафуриның иҗаты - - - шул чорларның барышында үзенчә билгеле бер хезмәт куйган бай әдәби мирас булып тора.* М. Җәлил.

18. *боерык ф. форм.* **куй, куегыз.** Берәр нәрсәне туктатырга яисә сөйләмәскә, эшләмәскә, калдырырга кушуны, инкяр итүне белдерә. *Куй, йөрәгем, янма артык.* М. Җәлил. *Куй, батырым, әйтә күрмә.* Дәрдмәнд.

19. *ярд. ф. функ.* 1) эш яки хәлнең тиз, кинәт башкарылуын белдерә. *Гыйльманов, балалар кебек, баскан урынында сикереп куйды.* И. Гази. *Елмаеп син бер көлеп куйдың.* М. Гафури; 2) эшнең нәтиҗәле булуын, төгәлләнүен белдерә. *Утынны да күп итеп ярып куйдылар.* Г. Бәширов. *Ишек алдын себереп күй алма тәгәрәтергә* Г. Тукай.

КУЯН *и.* 1. Кимерүчеләр отрядыннан озын колаклы кечерәк бер җәнлек. *Һәм дә бар монда куян, әрлән, тиен, йомран, поши.* Г. Тукай. || *с. мәгъ.* Куян тиресеннән тегелгән. *Куян бүрекле кыз чыннан да* [*каенны*] *бер кулы белән кочаклый һәм башын аның ап-ак кәүсәсенә сөяп куя.* Г. Әпсәләмов.

2. *сөйл.* Йорт куяны, кролик. *Куян асраучылык. Куян караучы.* □ [*Малай:*] *Үзем үстергән куяннар шул алар.* А. Әхмәт.

3. *күч. сөйл.* Куркак кеше. *Арсланнар алар — әнә болар, ә куян ул, Гата, син бугай.* Ш. Маннур. [*Нәгыймә Камиләгә:*] *Юләрләнмә инде, куркак куян.* Ш. Камал.

4. *күч. сөйл.* Билетсыз пассажир. *Поездда куян булып бару.* □ *Аннары - - - бер пароходта „куян“ булып Казанга килде.* Г. Минский.

Куян балтасы — бәләкәй балта, кечкенә балта. **Куян елы** — төрки халыкларда һәр елы бер аерым хайван исеме белән аталган борынгы унике еллык циклда дүртенче ел. *Куй елы кытлык, куян елы йотлык.* Әйтем. *Ул ел куян ел иде бугай.* Ә. Айдар **Куян ирене** — өске ирене тумыштан, куянныкы кебек, икегә аерылып торган (кеше турында). **Куян йоны** *бот.* — казаяклар семьялыгыннан сары чәчәкле үсемлек; фикария. *Куян йоныныңтәлгәшләре бик матур була.* Робинзон эзл. **Куян колагы** *бот.* — яфрагы өч аерчалы үсемлек; *русчасы:* дряква. *„Үги ана“, „аю табаны“ һәм „куян колагы“ яфракларының йомшак салкынчасы әз генә булса да тынычлык китергәндәй тоела.* Ш. Маннур. **Куян кузгалагы** *бот.* — өч йөрәкчек сыман яфраклы, урманда үсә торган үләнчел үсемлек; *русчасы:* заячий щавель. *Куян кузгалагын кузгалак урынына салатка, винегретка салалар.* Робинзон эзл. **Куян куыш** — балалар уены. *Сүз ахырында шундый җырсыз-сүзсез татар халык уеннарыннан кайбер миңа мәгълүм булганнарының исемен бирәм. Менә алар: туп уйнау, - - - куян куыш.* Н. Исәнбәт. **Куян кәбестәсе** *бот.* — сусыл яфраклы күпьеллык үсемлек; *русчасы:* заячья капуста. *Куян кәбестәсе коры аланнарда, калкулыклардагы куаклар арасында үсә.* Робинзон эзл. **Куян кәрешкәсе** *бот.* — кузаклылар семьялыгыннан терлек азыгы итеп кулланыла торган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* вика полевая. **Куян солысы** *бот.* — кыяклылар семьялыгыннан чүп үләне. **Куян сөяк** *бот.* — кузаклы үсемлек; *русчасы:* гороховник. **Куян талы** *бот.* — әремнең бер төре, исле әрем. **Куян эте** — куян куа торган ау эте.

◇ **Куян йөрәк(ле)** — куркак (кеше). *Яралылар, үзләренең чыннан да куян йөрәкле булуларына оялып,*

уңайсызланып, бер-бер артлы лазаретка керәләр. А. Шамов. [*Десятник:*] *Син куян йөрәк булып чыктың.* И. Гази. **Куян колагы калу** — бернәрсә дә калмау, нәрсә дә булса бетү турында. [*Якуп:*] *Хәлле кешеләр ташып бетерерләр дә ярлыларга тагын куян колагы гына калыр.* И. Гази. **Куян шулпасының шулпасы** — теге яки бу әйбернең яки күренешнең формасы белән генә шул әйберне яки күренешне хәтерләтүе, ләкин эчтәлеге белән ул әйбер яки күренеш белән бернинди дә уртаклык булмавы. — *Андый куян шулпасының шулпасы агай-энеләр күп булыр ул дөньяда.* С. Рафиков. [*Сафия Закирга:*] *Мәскәү кешесенең танышы булгач — [кияүгә] чыкмыйча соң! Куян шулпасының шулпасы диләрме әле? Нәкъ шушының төсле бу.* Ш. Камал. **Куян җан(лы)** — *к.* куян йөрәк(ле). [*Харис:*] *Уземнең куян җанлы булмавыма меңнәрчә шөкер итә идем.* А. Шамов.

КУЯНЛЫ *и.* Балалар уены. *Болдыр почмагында берничә малай куянлы уйныйлар.* Н. Исәнбәт.

КУЯНЧЫ *и. сөйл.* 1. Йорт куяннарын үрчетүче — караучы.

2. Куян аулаучы.

КУЯНЧЫК *и.* 1. Куян баласы. *Без икәү: әткә куян, әнкә куян, Ялгыз куянчыклар янә бездән туган.* Г. Тукай.

2. *ирк., кеч. к.* куян.

КУЯНЧЫЛЫК *и.* 1. Терлекчелек тармагы буларак, йорт куяннары үрчетү эше. *Куянчылык белән шөгыльләнү.* || *сөйл.* Йорт куяннары асрау белән шөгыльләнә торган хуҗалык. *Куянчылыкта эшләү.*

КУЭ *и. иск. юг.* 1. Нинди дә булса бер эшкә карата булган сәләт; берәр эшне эшли белү сәләте, башкара алу сәләте; талант. *Кешенең акылы камилләшү һәм фикер йөртү куәсе үсү дә — шундый ук законлы процесс.* М. И. Абдрахманов. *Гаҗәпкә каршы, үземдә сөйләү куәсе барлыгын гомеремдә беренче тапкыр диярлек сиздем.* А. Шамов.

2. Физик көч, куәт. *Җан вә тәннең барлык куәләре төкәмәлгә ирешкән дәвере башланганга мы, белмим, нидәндер, [Зыя белән Мәрьям] бу юлыгышуда әүвәлгеләргә бөтенләй башка бер хәл тойдылар.* Г. Ибраһимов.

КУЭТ *и. кит.* 1. Кешенең физик эш-хәрәкәт ясау сәләте, эш башкару сәләте; гайрәт, көч. [*Хәйдәр*] *бөтен куәте белән --- тормозны әйләндерә башлады.* Ш. Усманов. *Сафа боларны күргәч, бер кулын бутап торып, бар куәте белән кычкыра-кычкыра ыңгырашып җырлый башлады.* Ш. Камал.

2. Берәр төрле иҗтимагый күренешнең, мәсәләнең, илнең, җәмгыятьнең көче. [*Укытучы:*] *Нефть ул илнең куәтен арттыра.* А. Әхмәт. *Бөтен илнең материаль байлыгы, экономик куәте, машина техникасы искитәрлек тизлек белән үсә.* Г. Бәширов.

3. Производство объектлары (заводлар, машиналар, техник корылмалар турында). *Яңа производство куәтләрен сафка кертү.*

4. Берәр эш-хәрәкәтнең көче. *Бу дулкыннарның куәтеннән безнең юлдашлар инде пароходның идәненә егылып беттеләр.* Ф. Әмирхан.

5. Берәр күренешнең тәэсир көче, йогынты көче. *Бу хәлдән матбугатның никадәр куәткә малик икәнлеген аңларга мөмкин.* Г. Тукай. || *сөйл.* Тәэсир итү көче, катылыгы. *Керәннең куәте. Тәмәкенең куәте.*

6. *күч.* Рухи сәләт, рухи көч. [*Зәйнәп:*[*бу хакта булган кайгы-хәсрәтемне адәм куәте күтәрә алмас.* М. Гафури. *Туган иленә мәхәббәт, синең күңеленне баетып, бөтен тормышыңның мәгънәсен, тәмен, ямен мондый чакта тагын да ачыграк хис иттерә торган тиңсез бер куәт икән ул.* Г. Бәширов.

7. *сөйл.* Җегәрлек. *Тракторның куәте.* □ *Пароходны бөтен куәте белән баруында дәвам иттердем.* Ф. Әмирхан. || Эшләп чыгару сәләте. *Мортазин үзе директор итеп билгеләнгән „Казмаш“ заводының куәтен бик яхшы белә иде.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Куәт бирү** — 1) *к.* куәт кертү; 2) куәтләү, гайрәт бирү, дәртләндерү, җилкендерү. *Икенчеләре: „Нигә гел шәкерткә генә куәт биреп торасыз, әзрәк теге егеткә дә куәт биregез“.* М. Гали. *Дшнәләре куәт бирә: „Кычкыр, кычкыр“.* Ш. Маннур. **Куәт кертү** — көч бирү, көч кертү. *Гөлбикә куе каймакны минем алдыма таба этәрә дә: „Ашагыз, куәт кертә ул“, — ди.* Г. Ибраһимов.

КУЭТЛЕ *с.* 1. Зур физик көчкә ия булган, көчле. *Куәтле куллар.* □ [*Карт:*] *Алпамша, син үзең бик куәтле малай.* Әкият.

2. Зур иҗтимагый куәткә, көчкә ия булган. *Болар дөньядагы иң бөек, иң куәтле илнең солдатлары.* А. Шамов.

3. *сөйл.* Зур җегәрлеккә ия булган, зур җегәрлекле. *Куәтле экскаватор килә дә шул күкрәп үсеп утырган ашлыкны икегә ярып тирән канау казып китә.* А. Әхмәт. || Эшләп чыгару сәләте зур булган. *Республикада куәтле төзү оешмалары --- бар.* Соц. Тат.

4. Интенсивлыгы ягыннан зур; гайрәтле, көчле. *Һава аяз булса да, җил бик куәтле булганлыктан, бакчадагы агач яфраклары шау итеп шауламакта иде.* Ш. Мөхәммәдев. [*Диңгезнең*]*куәтле дулкыннары, тау-тау булып, биек, ташлы текә ярларга һөҗүм итәләр.* Г. Ибраһимов.

5. Сизү органнарына бик нык тәэсир итә торган, нык сизелә торган; көчле. *Нинди дер кыздан аңкып калган бик куәтле ислемай исе, тәмәке һәм сигара төтеннәренә кушылып, пар исенә буталып, Хәсәннең борынына керде.* Ф. Әмирхан. || *сөйл.* Тәэсир итү көче зур булган; зәһәр, каты. *Алып кайттым өйгә аптекадан Бик куәтле --- томау даруын.* М. Җәлил. — [*Сыраның*] *монысы тегесенә караганда да куәтлерәкме? Әллә ничек бугазларны чеметтереп төшеп киткән шикелле булды.* Г. Камал.

КУЭТЛЕЛЕК *и.* Куәтле булу, көчле булу; көчлелек дәрәҗәсе. *Дәүләтнең куәтлелеге.* □ *Күптән түгел [Первоуральскида] куәтлелеге ягыннан бөтен Европада икенче урында торучы гигант домна мичә салынган.* Соц. Тат.

КУЭТЛӘНДЕРҮ *ф.* 1. Көч бирү, көч, куәт кертү. *Саф, ачык һавада хәрәкәт итү, аның [баланың] эчендәге ашларны үзгәртеп, бәдәнен куәтләндерер.* Г. Тукай.

2. Үстерү, көчәйтү; арттыру. *Ш. Камал шушы сөйләгәннәрнең бер картинасын „Ут“ пьесасында безнең алдыбызга художество сурәтләрендә куәтләндереп биргән.* Г. Нигъмәти.

КУЭТЛӘНҮ *ф.* 1. Физик яктан көчәю, ныгу. *Аңарчы син дә үсеп куәтләнер идең.* Г. Тукай.

2. Тагын да көчәю, зуррак көчкә ия булу; интенсивлашу (эш, хәрәкәт, күренеш һ. б. ш. турында). [*Шәмгун*] *урамга чыкканда, яңгыр куәтләнгән, җил басылган иде.* А. Шамов. *Тышта тавыш куәтләнә.* Г. Камал.

КУЭТЛӘТҮ *ф. сөйл. к.* куәтләндерү. *Менә болар аның йөрәгендә уянган теге кызлык тойгысын куәтләттеләр генә түгел, Мәрьямне шул барлык гомерләрен гыйшык белән уздыра торган кыз каһарманнарның берсе, беренчесе кебек хис иттерә башладылар.* Г. Ибраһимов.

КУЭТЛӘҮ *ф.* 1. *сөйл.* Көчәйтү, көч бирү. *Илне куәтләү.*

2. Теге яки бу фикерне, сүзне, тәкъдимне һ. б. яклау; хуплау. *Башта барысы да бертавыштан шәһәрне саклауны куәтләделәр.* Ш. Усманов. *Бикмулла --- Гыйлажи сүзләрен куәтләде.* Ә. Еники. || Нигезләү, дөреслеген күрсәтү, дөреслегенә ышандыру. *Менә шул сүзне куәтләр өчен, монда бер мисал да китерермен.* Г. Тукай.

3. Нинди дә булса бер эш-хәрәкәтне башкарырга ярдәм итеп хуплап тору; җилкендерү, куәт бирү. *Дәүләт үзе [өй салуны] куәтләп тора, акчасын бирә, материалын бирә.* Ә. Еники. *Малай, тегесенең җырын куәтләп: ох! ох! ох! дип, ухылдап утыра иде.* Г. Бәширов.

4. Көчәйтү, үстерү, арттыру (берәр хисне һ. б. ш.). *Зыяның соңгы еллардагы эшләре аның бу өметен куәтли төшеп, тик Собраниедән имтихан кылынып чыгуы гына аның җанын бик дулкынландырды.* Г. Ибраһимов.

КУӘТСЕЗ *с.* 1. Физик яктан көчсез, көче аз. *Бу тавышлар диңгез буена җәелеп, карт дулкыннарны яшь итте, куәтсезгә көч бирде, куркакларга гайрәт бирде.* Г. Коләхметов.

2. Көчсез; гайрәтсез, куәте беткән. *Куәтсез керән. Куәтсез серкә.* || *сөйл.* Ышандыргыч түгел, ышандыру көче булмаган. *Куәтсез дәлилләр.*

КУӘТСЕЗЛЕК *и.* 1. Физик яктан көчсезлек, көч аз булу. *Мускулларның куәтсезлеге.*

2. Көчсезлек, тәэсир көче булмау. [*Газиз:*] *Никадәр куәтсезлек! Әни ясаган тәэсирне җуярлык тәэсир ясый алмыйм.* Ф. Әмирхан.

КУӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* 1. Физик яктан көчсезләнү, куәт бетү.

2. Көче бетү, көче кимү (кайбер күренешләр турында). [*Кояш*] *шулай үткән бер минутта түбәнәя, куәтсезләнә барып, ниһаять, бөтенләй югала — ак була, бетә.* Г. Ибраһимов. || Куәте бетү; тәэсирлелеге бетү (мәсәлән, керәннең).

КХ *аваз ияр. к.* кых. *Бетмәде шул, „Мөхбире" дә „кх, тфү".* Г. Тукай.

КХМ, КХХМ *аваз ияр. к.* кыхым. *Шәйхаттар --- кабат-кабат сорагач кына, көлеп җибәргән сыман иреннәрен кыймыл-кыймыл китергән дә: „кххм", — дип куйган.* И. Гази.

КХМЕР *и.* Кампучиядә яшәүче төп халык кешесе.

КЫБЫРДАТУ *ф. сөйл. к.* кыймылдату. *Гәүдәне кыбырдату.*

КЫБЫРДАУ *ф. сөйл. к.* кыймылдау. *Чыпчык кыбырдамый торалмый.* Әйтем. *Кыбырдаган кыр ашкан.* Мәкаль.

КЫБЫРДЫК *и. сөйл. к.* кыбырсык.

КЫБЫР-КЫБЫР *образлы ияр.* Селкенеп, селкенәселкенә; кыймылдап. *Ә ул — усал хатын — үзе кыбыр-кыбыр эшләп йөри, үзе сөйләнә.* Ф. Хөсни.

КЫБЫРСУ *ф. сөйл.* 1. Хәрәкәтләнү, хәрәкәткә килү, тынычсызлану. *Харис --- кыбырсып кузгалып утырды.* Г. Бәширов. || Тик тормау, эшләү. *Кыбырсыган кызыл кияр.* Мәкаль. [*Ике карт монах*] *үзләре дә йокламыйлар, бүтәннәргә дә тынычлык юк. Тик кыбырсыйлар шунда.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Җилкенү. *Шулай да элек йөргән якларын оныта алмыйча, һәрвакыт сагынып сөйли, бер язын, бер көзен, кыр казлары белән торналар кузгалган чакта, йөргә чуарланып, ул да бер кыбырсып ала.* Г. Бәширов.

КЫБЫРСЫК *с. сөйл.* Тик тормас, хәрәкәтчән, тынгысыз. *Кыбырсык кеше.* □ *Кыбырсык чапмас, ни утырмас, ни тынмас.* Әйтем.

КЫБЫРСЫКЛАНУ *ф. сөйл. к.* кыбырсу.

КЫБЫРСЫЛАУ *ф. диал. к.* кыбырсу. — *„Фәлән кеше" хатыны өстенә барып да аударырга мөмкин, кыбырсылап әллә кая бара алмас, диләр бугай.* Э. Касыймов.

КЫБЫРСЫНУ *ф. сөйл. к.* кыбырсу. *Кыбырсынып торган таза күк айгырны --- җиңел пролеткага җигеп --- шәһәр уртасыннан узып китүе үзе нәрсә тора!* Ә. Фәйзи.

КЫБЫРЖУ *ф. диал. к.* кыбырсу. [*Ярулла:*] *Бик кыбырҗысаң, син әнә колхоз басуларына барып җырла.* Ф. Бурнаш.

КЫДРАЧ *с. диал.* һавалы, масаючан. *Дөрес, ул бераз кыдрачрак булса да, малайлар арасында әтәч кушаматын тагып йөрсә дә, без аның белән шактый дус идек.* А. Гыйләжев.

КЫДРАЧЛАНУ *ф. диал.* Масаю, һавалану, әтәчләнү. *Кай арада кыдрачланып, вакланып китә торган яман гадәте бар шул аның.* А. Гыйләжев.

КЫДРАЮ *ф. диал. к.* кыдрачлану. [*Эскадрон сугышчылары*], *кыдраеп, шалт-шолт иттереп шпорларын бәреп йөрделәр шунда.* Г. Газиз.

КЫДЫРМА *с. диал. к.* кыдырым. *Комагай кылкыннан яза, кыдырма аягыннан яза.* Әйтем.

КЫДЫРУ *ф. сөйл.* Бер җирне калдырмыйча йөрү, йөреп чыгу. *Күп яшәгән белмәс, күп кыдырган белер.* Мәкаль. *Әйләнә җир шары, Галәмне кыдыра.* Х. Туфан. *Төмән, Пермь, Оренбург өлкәләрен дә кыдырып кайттык.* Ф. Хөсни.

КЫДЫРЫМ *с. диал.* Бөтен җирдә йөри торган, биләмче (кеше турында). *Кыдырым хатын өенә җиткәндә алгасыр.* Әйтем.

КЫЕГАЙТУ *ф.* Кыек хәлгә китерү, кыекландыру, кыйшайту. *Күпләр, --- көлке кыяфәтләргә кереп, башларын кыегайтканнар.* М. Әмир. *Габдәлхәмид кинәт авызын әллә ничек кыегайтып көлә башлады.* С. Рахманколый.

КЫЕГАЮ *ф.* 1. Кыеклану, бер якка авышлану, кыек хәлгә килү; кыйшаю, кыңгыраю. [*Җамалның*] *бүреге бер якка кыегайган.* А. Әхмәт.

2. *күч.* Бозылу, начарлану (мәсәлән, тормыш юлы).

◇ **Кыегаеп утыру** — күнелсезләнеп утыру, борын салындырып утыру. *Нәрсә син --- кыегаеп утырасың?* Ф. Бурнаш.

КЫЕК I *и.* 1. Корылманың, өйнең кыеклап эшләнгән түбәсе. *Ике генә тәрәзәле өй күренде: аның кыегына сыерчык оясы куелган, ә каршында миләш агачы үсеп утыра.* И. Гази. *Мостафа читәннең үреп бетергән, түбә кыегы агачлары ясап маташа иде.* Ш. Камал. || Кыек түбәнең эчке почмагы. *Өйнең башында, кыек очында, әлбәттә, һәр яз карлыгач оя ясый, бала чыгара.* Г. Ибраһимов. || *махс.* Нәрсәнең дә булса авыш итеп ясалган өслеге. *Затвор кыегы.*

2. *сөйл.* Кисәк, ярчык, кыйпылчык. *Көзге кыегы.*

3. *диал.* Тукыманы берәр нәрсә тегү өчен кискәннән соң калган вак кына кисәк, кисәк-косак. *Тукымадан калган кыеклар.* || Оч, яулык очы. [*Алар*] *башларына чуваш кызларыныкы кеби кечкенә яулыкны[ң] --- бер кыегын артка салындырып бәйлиләр.* З. Бәшири.

КЫЕК II *с.* 1. Горизонталь яки вертикаль яссылыкка яисә бер турыга карата ниндидер бер авышлыкта булган, авышлыкта торган, авышлык ясаган. *Кыек идән. Кояшның кыек нурлары.* | *рәв. мәгъ. Аннары, кыек бәреп, салкын яңгыр ява башлый.* А. Шамов.

2. Чалыш, чалышайган; кыегайган. [*Хәмидә:*] *Аның --- озын, шадра, кыек авызлы, кәкре аяклы кызын алмасам да, дөньяда киленсез калмам әле.* Г. Камал.

Кыек ашлама *а.-х.* — туфракка аның физик-химик үзлекләрен, структурасын яхшырту максатыннан чыгып кертелә торган ашлама. **Кыек килеш** *лингв.* — баш килештән башка теләсә нинди килеш. **Кыек налог (салым)** *махс.* — капиталистик илләрдә сатыла

торган товарларга яки хезмәт күрсәтүгә салына торган налог. *Кыек налоглар товарларның бәясен --- арттыралар.* Политэкономия. **Кыек почмак** *мат.* — туры почмактан кечерәк яки зуррак почмак. **Кыек сорау** *лингв.* — иярчен җөмлә ярдәмендә белдерелгән сорау. **Кыек сөйләм** *лингв.* — үзгәртелгән формада бирелгән башка кеше сөйләме. *Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндереп әйтергә мөмкин.* Татар теле грамматикасы. **Кыек тәмамлык** *лингв.* — төшем килешеннән башка килешләрдә килгән тәмамлык.

◇ **Кыек авыз** — гайбәтче. *Ана карчык кына, сүз йөртүче кыек авызлар киткәч, бик озак борчылып йөри.* А. Шамов. **Кыек атып туры тидерү** — читләтеп әйтеп үз фикереңне җиткерү, белмичә әйтеп дөресен сөйләү. *Кыек атып, туры тидергән вакытлар да булганга, ул бу юлы күп уйлап тормады.* А. Әхмәт. [*Муса:*] *Эзоп читләтеп суктыруны, кыек атып туры тидерүне уйлап тапкан.* Ш. Маннур. **Кыек күрү** — нәрсәне дә булса начар итеп санау, начарга чыгару. *Мин бу сүзне болай аңлыйм: әгәр бирәү бирәүгә каныкса, ул аның яманатын сатып йөри, һәр эшен кыек күрә, җай чыккан саен аңа бәйләнә.* Ә. Еники. **Кыек килмәү** — туры килү. *Әмма һәр җирдә тугры килгән „яшьлек — юләрлек“ мәкале безнең бала козгынга да кыек килмәде.* Г. Тукай. **Кыек көзгедә күрү** — ялгыш аңлау. *Мондый хәлләрдә җеп очын югалту, перспективаны кыек көзгедә күрү куркынычы бар иде.* Г. Әпсәләмов. **Кыек күз белән карау** — 1) шикле итеп, шөбһәле итеп карау; 2) читләтү, үз итмәү; игътибарсыз булу. *Бу мәсьәләгә кыек күз белән карарга ярамый.* **Кыек эш** — начар, гадел булмаган эш. *Кыек эшләр һәрвакыт диярлек кечкенәдән башлана.* Соц. Тат. **Кыек юл (сукмак)** — бозык юл, ялгыш юл; бозык тормыш. [*Шәмсин:*] *Үзең яшь кенә, ә кыек сукмактан йөрергә өйрәнеп тә өлгергәнсең.* С. Рафиков.

КЫЕКБАШ *и.* Ике яктан да очлары кыеклап киселгән таякчыкны икенче таякчык белән түгәрәккә сугып кертүдән гыйбарәт балалар уены. || Бу уенда кулланыла торган ике ягы да очлы таякчык, чүрәкәй.

КЫЕКЛАНДЫРУ *ф. сөйл. к.* кыегайту.

КЫЕКЛАНУ *ф. сөйл. к.* кыегаю. *Һава тын, завод трубаларыннан кара төтеннәр әкрен генә тузылып, кыекланып китә иделәр.* Ш. Камал.

КЫЕКЛАП *рәв.* 1. Нинди дә булса яссылыкка, турыга авышлык ясап, почмак ясап. *Ишектән кыеклап сузылган кояш нурлары күчеп йөриләр.* К. Нәҗми.

2. Өчпочмаклап, өчпочмак ясап, өчпочмак рәвешендә. *Малайлар --- колакларына җил кермәсен өчен башларына кыеклап яулык бәйләп, кулларына камчылар тотып атлар тирәсендә әйләнә башладылар.* М. Гали.

КЫЕКЛАТУ *ф.* 1. Кыегайту, авыш итү, авышландыру. *Зәңгәр конвертның тышында әре хәрефләр белән кыеклатып язылган адрес.* Г. Бәширов.

2. *рәв. мәгъ. к.* кыеклап 1. *Кыеклатып искән әче җилгә каршы асфальт юл белән атлады ул.* Э. Касыймов.

◇ **Кыеклатып карау** — кырын күз белән яисә астан карау. [*Миңнурый*] *Газинурга ачулы күзләре белән кыеклатып карап алды.* Г. Әпсәләмов. **Кыеклатып әйтү (сөйләү)** — читләтеп әйтү, киная белән әйтү, үз фикереңне турыдан-туры әйтмичә җиткерү. *Закир Шакирның кыеклатып әйтүен тиз абайлады булса кирәк.* Г. Минский.

КЫЕКЛАУ *ф. сөйл.* 1. Кыек ясау, кыек итү. 2. *к.* кыеклану. — *Тормыш юлы бер кыеклый башласа, аны турайту кыен була дип, укыганым бар.* С. Рафиков.

КЫЕК-МЫЕК *с. сөйл.* 1. Чалыш, чалыш-чолыш, нинди дә булса яссылыкка яки турыга карата төрле юнәлештә булган. *Кыек-мыек тактала.* □ — *Дөрес, һәммәсе дә элеккечә кебек: шул ук коргаксып беткән мичкәләр, шул ук кыек-мыек тәгәрмәчле ташландык арбалар.* М. Шабай. | *рәв. мәгъ. Машина --- дегет белән кыек-мыек „хода нет“ дип язып куелган аркылы тактага терәлеп, --- кырыйга борылды.* Р. Төхфәтуллин.

2. *куч.* Дөрес булмаган, ялган; начар. [*Шәмсин:*] *Кисәтеп куям: һаман кыек-мыек җавап кайтарсаң, үзеңне ныклап җавапка тартырбыз.* С. Рафиков.

КЫЕКЧА *и. сөйл.* Өчпочмаклы кечкенә яулык. *Кыекча башыңа чорнап, Урырсың ла баса җырлап.* Г. Кандалый. *Әбиләрнең --- яңарак кыекчаларына да, төрле төстәге чүпрәкләрдән корамалап эшләнгән яңа күкрәкчәләргә дә игътибарларын юнәлдерделәр.* Х. Кәрим.

КЫЕЛУ *ф.* 1. Кыйпылу, киселү, кыеп алыну. *Пулялар белән кыелып беткән зәңгәр кыңгырау чәчәкләргә гажәпләнеп карап тора иде.* И. Гази.

2. *сир.* Беленү, ярылу (таң турында). *Таң кыелгач, аккош көтүе кебек, Ак томаннар килеп чорнала.* Ә. Ерикәй.

КЫЕН *с.* 1. Башкару, үтәү өчен зур көч, тырышлык һәм хезмәт сорый торган. *Бик белемен: хәреф тезү — кыен бер эш, Кыен эшләр җиңелә, булсаң тырыш.* Ш. Бабич. *Күп разведкаларда аеруча кыен заданиеләрне Попов үти.* Ә. Айдар. || Аңлау, чишү өчен зур акыл көче сорый торган. [*Ирек:*] *Кыен мәсьәлә биргән идегез бит әле?* [*Илтуганов:*] *Бәлки, син эшләмәгәнсеңдер аны.* Д. Аппакова.

2. Авырлык, кыенлык, мохтаҗлыклар белән тулы, авырлыклардан гыйбарәт, кыенлыкларны үз эченә алган; мохтаҗлыклар һәм кайгылары күп. [*Айсылу*] *халыкның шундый кыен көннәрдә дә күңелен төшермичә, --- тырышып-тырышып язга хәзерләнүенә куана-куана атлый.* Г. Бәширов. || Четерекле, авыр, читен, уңайсыз. *Бу кыен хәлдән анасы коткарды аны.* А. Әхмәт. *Бәләкәйдән үк авыр эшкә җигелү, һәрнәрсәнең кыен ягын, авыр ягын гына күреп үсү тойгыларны тупасландырган булган күрәсең.* М. Әмир.

3. Шартлары уңайсыз, уңайлы түгел; кулай түгел, читен. *Урманнар, сазлар, таулар һәм исәпсез-хисапсыз күллар, елгалар белән капланган Карелия җире сугыш операцияләре алып бару өчен иң кыен урыннарның берсе санала.* Г. Әпсәләмов.

4. *и. мәгъ. сөйл.* Авырлык, читенлек, кыенлык. [*Камали:*] *Мондый кыен арасына һичбер вакытта да килеп кермәс идем.* Г. Камал. || Кыйналу, җәза алу. *Күпме кыен күрдек шуның өчен, күпме тал чыбыгы ашадык.* Һ. Такташ. *Ләкин ул* [*Сабира*] *тыела алмады, иреннән ашаган кыеннарын, әрнүләрен башкалар өстенә түгә торган булды.* Г. Ибраһимов.

◇ **Кыенга (туры) килү** — башкарып чыгуы авырга килү, читенгә әйләнү. [*Хәнәфи:*] *Эшлә, туган, кгыйсә Сабир бабайга кыенга килгәли.* Г. Әпсәләмов. *Яшьтән рәтләп укымагач, баштарак миңа кыенга туры килде.* Ә. Айдар.

КЫЕНАЙТУ *ф. сөйл. к.* кыенлаштыру. *Эшне кыенайту.*

КЫЕНАЮ *ф.* Кыенлашу, читенләшү, авырлашу, авырга әйләнү (эш һ. б. турында). *Электәге кебек үзеңне-үзең белештермичә эшләү кыенайды.* И. Гази.

КЫЕНЛАНУ *ф. сөйл. к.* кыенлашу.

КЫЕНЛАШТЫРУ *ф.* Читенләштерү, авырлаштыру, кыен хәлгә китерү. *Икенче яктан, ярлы хезмәт ияләре катлавына ул чорда гомумән юлның бикләнгән булуы үсү юлын шактый кыенлаштырды.* М. Җәлил.

КЫЕНЛАШУ *ф.* Берәр эшне башкару авырлашу, читенләшү. [*Тимери*] *Эше кыенлашкан саен ярсый гына барачак иде.* Г. Бәширов. || Кыенлыклар барлык-

ка килү, кыенлыклар күбәю, авырлашу. *Тормыш сәң дәрәҗәдә кыенлашты.* Ә. Фәйзи.

КЫЕНЛЫК *и.* 1. Кыен (1, 2 мәгъ.) булу. *Юлның кыенлыгы. Эшнең кыенлыгы.*

2. Авыр хәл, читен хәл, авырлык. *Золым, җәбер вә кыенлыкларны күтәрәләр шул кешеләр ки, кайсылары кан тирләргә батып эшлиләр, хезмәт итәләр.* Г. Тукай.

КЫЕНСЫНУ *ф.* 1. Читенсенү, тартыну, оялу. *Кыенсынып карап тору.* □ *Матур җиңги кыенсынды, бераз уңайсызланып елмайды.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр нәрсәне эшләргә теләмәү, авырсыну, батырчылык итмәү. *Миңа нинди дә булса җаваплы эш бирергә кыенсыналар.* М. Җәлил.

3. Кыенлык сизү, кыенлык күрү. [*Хәдичә*] *карчыклар нормасын, бер дә кыенсынмыйча, көтү кайтканчы ук тутырып, чүмәләсен куеп, бөтен эшен бетерә торган булды.* Г. Бәширов.

КЫЕНСЫТУ *ф.* Оялту, тартындыру, читенсендерү. *Бәлки, әнә шул ят күз карашлары аларны кыенсытып телләрен бәйдә тотадыр?* А. Гыйләҗев.

КЫЕРСЫТУ *ф.* Кимсетү, рәнҗетү; читкә кагу. *— Ай-яй, сине тегеләр кыерсыта башладылар.* К. Тинчурин. *Аларны мин яман яктан искә алмам: какмадылар, сукмадылар, әрәм тамак диеп кыерсытмадылар.* Г. Гали.

КЫЕРЧЫК *и.* 1. *сөйл.* Түгәрәк итеп пешерелгән икмәктән башлап кисеп алынган зур телем. *Куенында бер кыерчык икмәге, биш-алты алмасы, тозсыз суда пешерелгән өч-дүрт бәрәңгесе бар.* И. Гази.

2. *диал.* Икмәк салганда күәс төбен кырып алып пешерелгән кечкенә ипи.

КЫЕШ *с. сөйл. к.* кыек II. [*Галимә:*] *Кибәнегез - - - бер якка кыеш булып тора, шуны да менә дигән итеп сала белмәгәнсез.* М. Гафури.

КЫЕШ-МЫЕШ *с. сөйл. к.* кыек-мыек. *Кыеш-мыеш идәннәр. Кыеш-мыеш сызыклар. Кыеш-мыеш хәрефләр.*

◇ **Кыеш-мыеш сүз** — килешсез сүз, төрлечә аңлашыла торган сүз. [*Фәйзи:*] *Һичбер андый-мондый кыеш-мыеш сүз булмады.* Ш. Камал. **Кыеш-мыеш сөйләү** — килешсез, тиешсез сүзләр сөйләү; уен сүзләр сөйләү. *— Кыеш-мыеш сөйләгән булып, баланың башын катырасың.* Ш. Камал. **Кыеш-мыеш юл** — 1) бик үк туры булмаган алым, бик гадел булмаган юл; 2) читләтеп, астыртын эш йөртү. *Тик ул турыда кыеш-мыеш юлларга кермичә, мәсьәләне турыдан-туры ачып салу кирәк иде.* Ш. Камал.

КЫЕШУ *ф.* 1. *сөйл. Урт. юн. к.* кыю II.

2. *диал.* Бәхәсләшү, теге яки бу сүз белән килешмәү. *Галимҗан, - - - Оренбургка җыелган башкорт корылтаена барып, милләтче Зәки Вәлиди белән дә кыешып кайтты.* И. Рәмиев. || Алыш-биреш вакытында сатулашу, бәя турында бәхәсләшү.

3. *диал.* Маташу. *Юк белән кыешма.*

КЫЗ *и.* 1. Хатын-кыз женесеннән булган бала. *Ләлә - - - унөч яшьләрдә, матур, күбәләк кебек киенгән, очкын кебек кыз.* М. Фәйзи. *Гөлгенә — кыз бала, кызлар белән курчак уйный башлый, 9—10 яшьләргә җиткәч бик бирелеп чигүгә өйрәнә.* Г. Гобәй. || Ата-аналары өчен үзләреңең хатын-кыз женесеннән булган баласы. *Бу — Галиәсгарның кияүдәге кече кызы Фатыйма иде.* Ә. Фәйзи. *Инде минем кызым—комсомолка, Чәчләремә бара чал кереп.* Г. Хуҗи. || *с. мәгъ.* Хатын-кыз женесеннән булган. *— Безнең һәркайсыбызның кыз кардәшләребез һәм сөйгән ярларыбыз бар.* А. Шамов.

2. Хатын-кыз женесеннән булган һәм женси яктан өлгергән, кияүгә чыкмаган кеше; җиткән кыз. *Киенешеп-ясанышып килгән кызлар белән егетләрне һәм аларның уйнауларын карау өчен, шунда иптәш малайлар белән без дә бардык.* М. Гали. [*Хәсәнша*], *вакыт-вакыт сүз уңае белән шаярган булып, тагын да берәр яшьрәк хатын яисә картрак кыз алырга чамасы барлыкны әйтеп салгалаштыра.* Ш. Камал.

3. Кияүгә чыгучы кыз. *Халык шаулашып яратып кул чабып алды, кияү белән кызга карата мактау сүзләре әйтелде.* А. Шамов. *— Кияүгә ярәшелгән кыз, кияү янына кергәнгә тиклем, өйгә төшми, ахирәт кызлары белән елашып тик йөри.* М. Әмир.

4. *сөйл.* Фахишә, бозык хатын. *Җиңгәчинең төне буе бар кызлары Хажи байны сый итәләр төрлечә.* Г. Тукай. *Бай абзыйның акчасы күп, Рәхәт тора кызлар кочып.* Н. Исәнбәт. || Сөяркә. *Байлар әчәләр, тарталар, карта уйныйлар, бишәр җирдә матур кыз асрыйлар.* Г. Ибраһимов.

Кыз алу — кызны хатынлыкка алу, кызны хатын итеп алу. *— Алар кыз алып, кыз биреп, кан катыштыралар.* Г. Бәширов. *Бер-берсен кәфер дәрәҗәсендә санашып, кыз алышмыйлар.* З. Һади. **Кыз багу** *этн.* — кияүнең һәм аның туганнарының кыз белән танышу йоласы. **Кыз бирү** — кызны кияүгә бирү, кызны хатынлыкка бирү. *— Исмәгыйль кебек байга кыз бир дә, имеш, ике йөз белән эш бетер.* М. Фәйзи. **Кыз бүләге** *этн.* — кызның ата-аналарыннан яки якын туганнарыннан, кызны кияүгә бирергә ризалык алгач, аерым акча бәрабәренә килешү билгесе итеп алдан бирелә торган бүләк (ашъяулык, яулык, җәймә, кулъяулык, янчык һ. б.). *Шунда ук егерме биш тәңкә акча чыгарып салып, кыз бүләген алып кайткан.* Г. Ибраһимов. **Кыз димләү** — кемгә дә булса билгеле бер кызга өйләнергә тәкъдим итү, өйләнергә киңәш бирү. **Кыз елату** *этн.* — кызны озату алдыннан аның якыннарын һәм иптәш кызларын җыеп, аларның кыз исеменнән моңланып бәет әйтүеннән гыйбарәт мәҗлес. *Саулармы сез, абыстакайлар, Кызны елатырга килдек без.* Җыр. **Кыз качыру** *этн.* — *к.* кыз урлау. *Боларда кабилә челек талашлары, җәйләүләре, кымызлары, калымнары, кыз качырулары, тагын әллә нихәтле безнең өчен яңа, ят булган экзотикалары белән күз алдына бастырылган казакъ хәяты да бар.* Г. Нигъмәти. **Кыз килешү** *этн.* — ата-анасыннан яки якын кардәшләреннән кызны кияүгә бирергә ризалык алу. *Болар тотканнар да миңа күрше авылдан бер кыз килешеп куйганнар.* Г. Ибраһимов. **Кыз куенына керү** *этн.* — кияүгә чыгучы кызның өендә кияүнең кыз белән беренче тапкыр йоклавы турында әйтелә. *Туй булып, егет кыз куенына керер кичне, кыз кинәт юк булган.* Ә. Фәйзи. **Кыз күзләү** — кәләш алыр алдыннан кызларны сынап-тикшереп йөрү; кәләшлеккә кыз сайлау. *Әллә кыз күзләргә килдегезме?.. Шулай булса, кире борылыгыз!..* Ә. Ерикәй. **Кыз озату** *этн.* — кияүгә чыккан кызны кияү өенә җибәрү, озату. || Шуның белән бәйләнгән йола. *Сезнең дүртегезне бер вакытта хатыннарыгыз белән парлап кунакка чакырам: - - - җәй көне — печәнгә төшәр алдыннан, яшь тәкәләр өлгергәч, авылда кыз озату, килен төшерү көннәрендә.* Г. Ибраһимов. **Кыз сорау (яучылау)** — кызның ата-аналарыннан яки якын кардәшләреннән аны хатынлыкка сорау, кәләшлеккә үтенү. *Кем икәнеңне беләсең килсә, кыз сорат.* Мәкаль. **Кыз урлау** *этн.* — кызны аның ризалыгыннан башка ата-анасыннан яки якын кардәшләреннән урлап хатынлыкка алу. *Кияү егет тә булдым, башкода да булдым, кыз да урлаттым.* Г. Әпсәләмов. **Кыз ябыштырып чыгару** *этн.* — кыздан ризалык алып, туй үткәрмичә генә өйләнү. [*Солдатка алынучыларның*] *кайберләре, китәргә өч кенә көн калгач, кыз да ябыштырып чыгаралар.* М. Гали. **Кыз ярәшү** *сөйл., иск.* — кызны кемнең дә булса кәләше итеп белдерү, кәләше итеп игълан итү.

КЫЗА *и. зоол.* Карчыгалар семьялыгыннан ерткыч кош; *русчасы:* мышелов.

КЫЗАЛАК *и. бот.* Лаләләр семьялыгыннан калпак рәвешендәге матур чәчәкле күпьеллык декоратив үсемлек; *русчасы:* тюльпан. *Тау сыртларында янып торган кызалаклар балкыган.* Д. Аппакова.

КЫЗАМЫК *и.* Тәнгә вак тимгелләр-бөрчекләр чыгу, сулыш юлларының ялкынсынуы, температура күтәрелү белән үтә торган йогышлы балалар авыруы. *Соңгы елларда күп уку һәм язу аркасында, Габделкаюмның кызамыктан бозылып калган сул күзе еш кына авыртсалап борчый башлады.* М. Гали.

КЫЗАРТКЫ *и. сөйл.* Мичтә күмәч, ипи пешергәндә мич алдына өеп куелган куз, утлы күмер.

КЫЗАРТМА *и. кулин.* Сыер итен юка гына итеп турап башта кыздырып, соңыннан шулпада томалап пешерелгән ашамлык. *Кызартма табынга кайнар көе бирелә.* Татар халык ашлары.

КЫЗАРТУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса кызыл төскә кертү, кызылландыру. *Кояш шәүләсе кызарткан оешык болытлар фикергә калган төсле күренә иделәр.* Ш. Камал.

2. Кеше тәне турында: кызылсу төскә кертү, кызылландыру (бу хәл канның тирегә күбрәк килүе сәбәпле була). *Нервлар шаярмасын, идарә көче йомшармасын дип, [Мостафа] һәр иртә-кич бозлы су белән тәнен ышкыды. Сөлге белән кызарткачы сөртенде.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Оялту, оялтып йөзен кызылландыру; уңайсыз хәлдә калдыру. *Кечкенә кызның бу соравы мине бераз кызартып җибәрде.* М. Гали. *Михаил Хәятка --- урыны килгәндә комплиментлар әйтеп китәргә дә онытмый һәм бу эше белән Хәятны кайсы вакыт кызартып та җибәрә иде.* Ф. Әмирхан.

КЫЗАРУ *ф.* 1. Кызыллану, кызыл төскә керү. *Кич җитеп офык кызарганда, [Рәүфнең гәүдәсен] авыл артында калкулыкта җирләделәр.* Г. Минский. || Җиләк-җимеш турында: пешеп җитеп, өлгереп кызыллану, кызыл төскә керү. *Алмалары, хөрмәләре кызарып пешәр әле.* Җыр. *Бакчада чияләр кызарып килә.* И. Гази

2. Канның тән тиресенә күбрәк килүе аркасында тән кызылсулану, тәнгә кызылсу төс керү. *Суыкта кызарып, матураеп, Хәлим кайтып керде.* И. Гази. *[Газинур] теге вакыттагы хатасы өчен оялып, комач кебек кызарды.* Г. Әпсәләмов. || *күч.* Оялу, уңайсызлану. *[Маһибикә], минем карашыма җиңелеп, башын ия дә кызара, серле итеп елмая.* М. Әмир.

КЫЗАРЫНУ *ф.* 1. *сөйл.* Кызару, кызыл төскә керү. *Бит-күллары кояшта кызарынган, бригадирлары кебек үк таза-таза биш-алты кыз, үзара нидер сөйләшә-сөйләшә, алдан кайталар иде.* Г. Бәширов.

2. Йөз кызару, йөзгә кызыллык йөгерү (оялудан, уңайсызланудан һ. б. ш.). *Рәүфә комач төсле кызарына.* А. Шамов. *Килен-кыз вә --- Маһитап абыстай кызарындылар, оятларыннан нишләргә белмәделәр.* Ф. Әмирхан.

КЫЗАРЫНУ-БҮРТЕНҮ *ф. сөйл.* Ачудан, көчәнүдән һ. б. ш., бит мускуллары хәрәкәткә килеп, йөз кызару. *Мулла, кызарынып-бүртенеп, авызыннан күбекләр чәчеп, сүзен әйтә алмый, таягын күтәреп алар өстенә ташланды.* М. Гали. *Ул мескен кызарып-бүртенеп читкә барып утыр[а].* Ак юл.

КЫЗАУ *и.* 1. Җиләк-җимеш җыю яки сибелүчән, чәчелүчән әйберләрне салып кую өчен юкәдән, кабыктан, чыбыктан һ. б. ш. ясалган төрле зурлыктагы савыт. *Каюм, тал чыбыклары китертеп, үзенең квартира ишек алды бакчасына зур читән кызаулары үреп куйды.* Ш. Камал.

2. *диал.* Юкәдән ясалган зур тубал — ашлыкны кул **белән** чәчкәндә кулланылган.

КЫЗГАНДЫРУ *ф.* Кемдә дә булса кызгану хисе уяту. *Тагын да кызгандыра төшү өчен, Хәлим үзен әнисез дә итеп, түгәрәк ятим итеп күрсәтмәкче иде.* И. Гази. — *Үземчә хатны бик дәртле, кызгандырырлык, кызларны сокландырырлык итеп яздым.* Ә. Айдар.

КЫЗГАНУ *ф.* 1. Авыр хәлдә калган кешегә теләктәшлек белән карау, кемне дә булса жәлләү. *Ул һаман да мине кызгана.* М. Җәлил. *Бабайны авыл байларыннан башка бөтен авыл кызганды.* Г. Гали. || Кемгә дә булса шәфкать күрсәтү. *Казый абзый! Безне син кызган, — дибез.* Г. Тукай. *Кечкенә Зарифулланы --- Габдуллажан, кызганып, үз тәрбиясенә алып кала.* Г. Минский.

2. Жәлләү, әрәм дип санау. *Өч минут вакытны кызгану.*

3. Саклау, бирмәү; сарыф итмәү (нәрсәне дә булса). *Үзем сөйгән илем өчен, Кызганмыйм бөтен көчем.* Н. Исәнбәт. || Бик саклап тоту, бик саклап сарыф итү. *Фәттах акчаны кызганмады.* Ә. Фәйзи.

КЫЗГАНУЛЫ *с.* 1. Кызгану хисе булган; жәлләү хисе булган. *Кызганулы караш.*

2. *к.* кызганычлы. *Кызганулы хәл.*

КЫЗГАНУСЫЗ *с.* Жәлләү хисе булмаган, кызгану хисе булмаган; шәфкатьсез, аяусыз. *Тупка каршы тупның җавабы бар. Бу җавап каты була. Кызганусыз була.* К. Нәҗми.

КЫЗГАНЫЧ *с.* 1. Жәлләү хисе уята торган, кызгану хисе тудыра торган. *Мин, аның бу кадәр кызганыч хәлдә калуын күреп, бераз йомшардым.* М. Әмир. || Кызгану белдерә торган. *Рәшид, кызганыч йөз белән, астында калып егылган үләннәрне торгызып маташа иде.* Ак юл. | *рәв. мәгъ. Картның торышы, төсе байтак кызганыч күренде.* Г. Ибраһимов. | *хәб. функ. [Сәрвәр:] Синең шунысы бик кызганыч: сүзләрең күп, үзең юк.* Т. Гыйззәт.

2. Бик мескен булган, кызгану хисе уята торган; ярдәмчесез. *Ул шунда гомерендә беренче мәртәбә үзенә-үзе бик кызганыч, бик бәхетсез кеше булып тоелды.* Г. Бәширов. | *рәв. мәгъ. Нури миңа чиксез, чамасыз кызганыч тоела башлады.* Ф. Әмирхан. | *хәб. функ. Ул бу вакытта елаганнан да артык кызганыч иде.* Г. Гобәй.

3. Авыр кичерешләр уята торган, фаҗигале. *[Мәрьям] ниндидер бер кызганыч роман укып, күз яшьләре дә түкте шикелле.* Г. Ибраһимов.

4. *сөйл. кер. сүз функ. к.* кызганычка каршы.

◇ **Кызганычка каршы** *кер. сүз.* — берәр вакыйга, күренеш уңае белән үкенү белдергәндә әйтелә. — *Бик чибәр сөйкемле кыз дип ишеттем, ләкин, кызганычка каршы, күрергә туры килгәне юк әле.* Ә. Еники.

КЫЗГАНЫЧЛЫ *с.* 1. *к.* кызганыч 1. *Кызганычлы караш.* □ *Кызганычлы бер кыяфәт, яшьле күз берлә Мескен баш болай дип башлый сүз.* Г. Тукай.

2. Фаҗигале, авыр кичерешләр уята торган. *Бервакыт, Мохтар унбер-унике яшьләрдә булгандыр, аларның өендә бик кызганычлы хәл булды.* Ш. Камал.

КЫЗГАНЫЧСЫЗ *с.* Кызгану, жәлләү хисе уятмый торган. *Шул көннән алып авыл байлары, җирләре тартып алынган алпавытлар --- кызганычсыз рәвештә үч алу эшенә керештеләр.* Г. Гали. || *рәв. мәгъ.* Кызганмыйча, жәлләмичә, кызганмый. *Язмыш кайбер вакытта бичара адәмнең өстеннән үтә кызганычсыз көлеп куя.* Г. Ибраһимов.

КЫЗГЫЛТ *с.* Беркадәр кызыл, аксыл-кызыл, кызылсу; ачык булмаган кызыл. *Кызгылт буяу. Кызгылт стена.*

КЫЗГЫЛТ КӨРӘН *с.* Кызылсу көрән, беркадәр кызыл булып күренгән көрән. [*Шәмсетдин*] *кызгылт көрән битендәге итләч озын борыны, озын кара мыегы, яшьләй агарган каты чәче белән үк көньяк халкына тартым кебек.* Г. Бәширов. [*Көз*] *чия белән шомырт яфракларын күз алдында кызгылт көрән төскә манып чыкты.* Г. Гобәй.

КЫЗГЫЛТ САРЫ *с.* Кызыл төс белән сары төс арасындагы, кызылсу сары, беркадәр кызыл булган сары; әфлисун төсендәге. *Болар кайтканда көн кичеккән, батып барган кояшның кызгылт сары нуры белән иге-чиге күренмәгән хәтфәдәй яшел сахрадагы күлләр, алтындай ялтырап, күңелгә рәхәт, тыныч матурлык биреп торалар иде.* Г. Ибраһимов.

КЫЗДЫРГЫЧ *и. мед.* Кайнар суга яки даруга манып алып тәннең авырткан урынына куела торган бәйләвеч, припарка.

КЫЗДЫРМА I *и. кулин.* Таба яки башка шундый берәр савытта майда кыздырылган ашамлык.

КЫЗДЫРМА II *с. техн.* Кыздыру юлы белән эшли торган. *Кыздырма кабызгыч.*

Кыздырма без — кыздырып нәрсәне дә булса өтеп тишү өчен хезмәт итә торган без. **Кыздырма лампа** *физ.* — вольфрам чыбыкны ток белән кыздырып яктылык бирә торган электр лампасы. *Рус инженеры А. Н. Лодыгин уйлап тапкан кыздырма лампа Яблочков шәменә алмашка килде.* Физика.

КЫЗДЫРУ *ф.* **1.** Каты әйберне югары температурага җиткәнче утта тоту; эсселәтеп каты әйбердә югары температура барлыкка китерү. *Сәйфулла хәзрәткә акчасын ышкып, кыздырып тоттыра, хәзрәтнең кулы пешә.* Ф. Бурнаш. *Мәхмүт Насрыйның кәйләсен алып учакка кыздырырга куя.* Ш. Камал.

2. Кояш турында: һаваны бик нык җылыту, эсселәтү. *Кояш шундый кыздыра, һич тә көз көне дип әйтерлек түгел.* И. Гази.

3. Нәрсәне дә булса майлы табада яки башка шундый берәр савытта кызуда тотып, ашамлык итеп хәзерләү, пешерү. *Бәрәңге кыздыру.* □ *Кайбер көннәрне алар Чаганга төштеләр һәм анда тотылган кечкенә чабакларны шунда ук кыздырып ашадылар.* Ә. Фәйзи.

4. *күч. сөйл.* Ачулану, бик каты тиргәү, орышу. *Инде сүзне синең хатыңа борыйк; хәзер мин сине бераз кыздырып алмакчы булам.* Г. Тукай. *Директорның кыздыра торган гадәте юк иде.* Д. Аппакова.

5. *күч.* Ярсыту, теге яки бу эшне уңышлы башкарырга хәзерләү (мәсәлән, ярышлар алдыннан атны). *— Д ат аягы кыздырганны күргәнең бармы?* Г. Ахунов. [*Госман*] *колагына яулык бәйләгән, ал күлмәген балкытып, атның аякларын кыздырып йөргән була.* Ф. Хөсни. || Җилкендерү, дәртләндерү, дәрт бирү. *„Бер шигырь яз!" — дип мине кыздырса дәрт.* Ш. Бабич.

6. *күч.* Көчәйтү; арттыру. *Гәрәй дә, Госман да аның сүзен тыңладылар, талашны кыздырмадылар.* Г. Ибраһимов.

7. *с. мәгъ.* **кыздырган.** Нәрсәне дә булса (итне, бәрәңгене, балыкны) берәр майлы савытта кызуда тотып, ашамлык итеп әзерләнгән. *Кыздырган бәрәңге. Кыздырган балык.*

Кыздыру батареясы *физ.* — берничә гальваник элемент яки аккумулятор ярдәмендә электр тогы алу җайланмасы. **Кыздыру шары** *физ.* — двигательләрдә: бөркелеп кергән ягулыкны кабызу өчен хезмәт итә торган камераның бер өлеше.

КЫЗ-КЫМЫЗ *җый. и. сөйл. к.* кыз-кыркын 1. *Д Нурулла кызлар күзенә ешрак чалынырга кирәк, Гаделияне күреп әйтмәсләрме дигән өмет белән, тагын кыз-кымыз тирәсенә елышты.* И. Гази.

КЫЗ-КЫРКЫН *җый. и. сөйл.* **1.** Төрле яшьтәге кызлар. *Укымышлы малайны күреп кенә чыгар өчен күрше-күлән, кыз-кыркын әллә никадәр сылтаулар тапты.* Ә. Фәйзи. *Яшь егетләр, кыз-кыркыннар Болыннарга чыгарлар.* Ә. Ерикәй.

2. *тар.* Сугышта әсиргә төшерелеп колга әйләндерелгән хатын-кызлар.

КЫЗЛЫК *и.* **1.** Кыз хәле, кыз булу халәте. [*Мәрьям*] *ачык, аңлы карашлы кызлар, китаплар, сөйләнгән яңалыклар эчендә, үзенең кызлыгын, кыз йөрәклеген сизә башлады.* Г. Ибраһимов. *Каргалының атларында Тезген бавы мунчала, Кызлыкларын белдергәннәр Су илткәндә мунчага.* Бәет. || *с. мәгъ.* Кыз кешегә хас, кызга хас. *Миңнурый күңеле нечкәреп китүдән оялыпмы, әллә кызлык горурлыгыннанмы - - - яңадан үзенең чәнечкеләрен өскә чыгарды.* Г. Әпсәләмов.

2. Кыз булып яшәгән вакыт, кыз булган вакыт; кызның кияүгә чыкканчы үткән вакыты. *Хәтта берничә мәртәбә бик юктан гына күзләре яшәргәнен һәм, шул ук минутта анасы өенә кайтып, үзенең кызлыгы үткән бүлмәсендә бикләнеп бик озак елаганын сөйлиләр.* Г. Ибраһимов. | *с. мәгъ. Хәят кызлык вакытын күңел ачлыгы белән үткәрде.* Ф. Әмирхан. *—Миңа кызлык гомере күңелле.* Г. Тукай.

3. Гыйффәт.

Кызлыкка алу — чит кеше кызын үз баласына карата булган кебек хокуклар биреп семьяга алу, семья әгъзасы итеп алу. — *Шушы баланы үзебезгә кызлыкка алып үстердек.* Ш. Камал.

КЫЗЛЫКЛЫ *с.* Гыйффәтле, җенси мөнәсәбәттә булмаган. *Яңалык — кызлыклы кыз кебек, Искелек— тол хатын кебек.* Мәкаль.

КЫЗМА I *и. сир. к.* эретмә. *Мартен миче төсле утка манчып Өстән койды корыч кызмасын.* М. Җәлил.

КЫЗМА II *и. сөйл.* Кызулык, ярсу. [*Шәкерт:*] *Үземне үзем белмичә, чиктән тыш бер кызма белән кармакны яр башына аттым.* Г. Ибраһимов.

◇ **Кызма тоту** *сир.* — кызмача хәлгә килү, исерү. *— Тәмам шунда исердек, Бөтен бит-баш кызарды, тотты кызма.* Г. Тукай.

КЫЗМАЧА *с.* Исерткеч эчемлек эчеп бераз исереп алган, беркадәр исерек. *Аның кызарган күзләреннән һәм телләре шактый көрмәкләнүеннән Габдулла килүченең кызмача икәнен белеп алды һәм сәламне кайтармады.* Ә. Фәйзи.

КЫЗМАЧАЛЫК *и.* Беркадәр исерек булу.

КЫЗ-МЫЗ *җый. и. сөйл. к.* кыз-кымыз.

КЫЗТӘКӘ *и. гади. с.* **1.** Ике төрле җенси әгъзасы булган кеше, хонса, гермафродит.

2. *кимс.* Хатынша, хатын-кызлар эшенә тыгыла торган ир кеше.

3. *кимс.* Үзенең кыланыш-торышы белән ирләргә охшарга тырышкан кыз, үз-үзен ирләргә охшатып тоткан кыз.

КЫЗУ I *ф.* **1.** Эсселәнү, югары температура барлыкка килү (берәр предмет турында). *Тимер кызган саен, чүкечләү яхшы буладыр.* Г. Тукай. [*Җиңги*] *чытырдап торган кызган табага әче камырны салып җибәрде.* Ә. Айдар.

2. Һава эсселәнү, һаваның температурасы югары күтәрелү турында. *Тик кызган һава тиз генә суынмады.* Г. Гобәй. *Көн кызды.* Дәрдмәнд.

3. Утта пешү, пешеп ашамлык хәленә килү. [*Хуҗа хатын:*] *Хәзер самовар куям, аңарчы стерләдләрем дә кызарлар.* Г. Ибраһимов. *Бераздан борыннарга утта кызган бәрәңге исе бәрелде.* К. Нәҗми.

4. Юешлектән, дымлылыктан җылынып бозылу, чери башлау (печән, ашлык һ. б. ш.). *Гәрәбә бодай-*

лар каралалар, күгәрәләр, кызалар, төтенләп яна башлыйлар. И. Салахов.

5. Кан күбрәк килү аркасында тән эсселәнү. *Ул үзе яңакларының бик озак кызып торуын сизеп алды.* Г. Әпсәләмов. *Тәннәрем бер кызды, бер туңды.* М. Әмир.

6. Тизлекне арттыру, йөрешне тизләтү. *Трактор төтен чәчеп кызып китте.* М. Гафури. *Баш килә, шундый каты, шундый кызып, полный ход килгән трамвайдан узып.* Г. Тукай.

7. *күч.* Җанлану, җанланып китү; шәбәю, интенсивлашу. *Промыслоларда эшләр әле кызып китмәгән, шулай да гомумән җыену хәрәкәте башланган иде инде.* Ш. Камал. || Көчәю, көчәеп китү. *Сугыш кызганнан-кызга барды.* □ *Ләкин ачу моның белән бетми, Кызган саен кыза тагын да.* З. Мансур. *Авылда хәзерге көндә сыйнфый көрәш иң кызган вакыт.* Һ. Такташ. || Зур киеренкелек барлыкка килү, вакыйгалар катлауланып китү. *Сәяси тормыш кызып, тыныч тору дәверенең канлы корбаннарын китереп чыгаруга барып җитә.* Г. Нигъмәти.

8. *күч.* Ярсу, ярсып китү; әсәрләнү. *Сапай карт кызды, тирги-тирги яшьләрне акылга утырта башлады.* М. Җәлил. *Гыйззәтнең нервлары кузгалган, бертуктаусыз кыза.* Ш. Усманов.

9. *күч. сөйл.* Беркадәр исерү, исерек хәлгә килү. *Батыргали агай, бик исерек булмаса да, яхшы ук кызган, күз аллары томалана башлаган иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Әхмәди яхшы ук кызган, башкалар да бераз кызмачалар, егет гармонен бик нык тартып уйный.* А. Әхмәт.

10. *күч.* Кызыгу, кызыксыну уяну. *Хатка каршы хат языйм! Эчтән уйлыйм: — Туктa, дим, кызлар кызарлык шәп языйм.* Ш. Бабич.

◊ **Кызган баштан** — исерек килеш, исерек хәлдә. *Җамали [эшне] бүгеннән калдырмау исәбе белән кызган баштан бик нык тотынды.* Г. Ибраһимов. **Кызган табага бастыру (утырту)** — кемне дә булса бик нык тиргәү, орышу. *[Шәйхулла:] Әхмәтне дә кызган табага бастырып биетермен.* Д. Аппакова.

КЫЗУ II *с.* 1. Кызган, эсселәнгән; югары температуралы, бик эссе. *Кызу тимер. Кызу мич. Кызу мунча.* □ *Зәйтүнә, алачык учагындагы кызу ялкынга төшеп баруын аңлап, куркынып кычкырды.* К. Нәҗми. *Ул, астындагы ылысларны кызу костёр янына якынрак күчереп, ипләбрәк яткты.* Г. Гобәй. || *рәв. мәгъ.* Югары температура хасил итеп, эссе булырлык итеп. *Кызу яну.* □ *Мунча үзе, кергәч тә башны куырып алырлык итеп, кызу ягылган.* М. Гали.

2. Эссе һавалы, эссе. *Кызу җәй уртасы җитсә, авыллар төшәләр эшкә.* М. Гафури. || *и. мәгъ.* Һава эсселәнүенең, җылынуының югары дәрәҗәсе, эсселек. *[Шәйхи:] Бу каһәр төшкән кызудан кайда да качып котыла алмассың.* Ш. Усманов. *Төш ауган, һава бераз талчыкланган, көндезге кызу да кайткан.* Г. Ибраһимов. | *рәв. мәгъ. Кояш бераз кызурак итеп карый башлау белән Көмешле күленең саерак урынларында камыш баш калкыта башлый.* Г. Гали. | *хәб. функ. Көн кызу. Чыпчыклар авызларын ачып күләгәдә утыралар.* И. Гази.

3. Зур тизлекле, тизлеге зур булган; бик тиз бара торган, бик тиз ага торган, бик тиз үтә торган. *Кызу агым.* □ *Ишек алларында, тыкрыкларда, урамнарда кызу хәрәкәт башланды.* Г. Бәширов. || *рәв. мәгъ.* Тиз, шәп, ашыгып. *Әллә кызу барганга, әллә Гали абзыйның сүзләре бик кызык булганга, Бөгелмә юлы бик кыска булып чыкты.* Г. Әпсәләмов. *Агыйдел, бу тәңгәлдә кызу акмаса да, безне шактый алып китәргә өлгергән иде.* М. Әмир.

4. *күч.* Киеренке, ашыгыч эшләр күп булган. *Кызу печән өсте узып китте, уракка да төштеләр.* А. Шамов. *Бик кызу чак, ятма йоклап, Анда чап та монда чап.* Ш. Бабич. | *хәб. функ. [Ирбулат:] Беләсең, бездә хәзер эш нинди кызу.* Р. Ишморат.

5. Бик көчле, киеренке, каты. *Яңадан бер-ике сәгатьлек гаять кызу сугыштан соң дошман көймәләре качарга тотындылар.* Ф. Әмирхан. | *рәв. мәгъ. Биредә атышлар кызу булды һәм озакка сузылды.* Г. Гобәй. || Киеренке, вакыйгаларга бай булган. *Бу еллар — кызу сыйныф көрәше, революция көрәше еллары.* Г. Нигъмәти.

6. *күч.* Бик көчле, дәртле, тирән (хис турында). *Кызу дәрт.* □ *Алар кызу, кайнар мәхәббәт белән тулган хатлар языштылар.* А. Шамов. || Хисле, тойгылы, хискә бай, тойгыга бай. *Гөл битеннән үпсәм, кызу ирнем белән, Бар вөҗүдемне илаһи бер мөкатдәс нур баса.* М. Гафури. | *и. мәгъ.* Дәрт, көчле хис. *Кызу сүнде йөрәктә.* Г. Тукай. *Йөрәкләрендә утыз ел элек кабынган мәхәббәт ялкынының кызуы басылмады.* Г. Минский.

7. *күч.* Тиз ярсый торган, тиз әсәрләнүчән, тиз кабынучан, хискә тиз бирелүчән.

8. *рәв. мәгъ.* **кызуында.** Кызган вакытта. *Тимерне кызуында сук.* Мәкаль.

◊ **Кызу канлы** — тиз ярсый торган, тиз ярсучан, тиз әсәрләнүчән. *Сиражи, әлеге дә баягы дигәндәй, бик кызу канлы кеше булгач, онытылып китеи балтага сузыла.* Г. Минский. **Кызу канлылык** — тиз ярсый торган булу, тиз әсәрләнүчән булу, хискә бик тиз бирелү. *Кызу канлылык күп вакытта эшне боза.* **Кызу кулдан** — бер кызгач, бер кызып киткәч. *Кызу кулдан [бу эшне] бетереп алдык.* Г. Ибраһимов. **Кызу табигатьле (холыклы)** — *к.* кызу канлы. *Кызу табигатьле, көчен кая куярга белми торган Григорян үз взводына күтәренке күңел белән кайтты.* Г. Әпсәләмов. **Кызу тоту** — 1) тиз эшләү, тиз башкару. *Кызу тотмаганда, даладагы печәннең дә чабылмый калуы куркынычы бар.* Ш. Камал; 2) ашыктыру, тизләтү. *Алар вакытны бик кызу тотарга һәм бөтен эшне күз ачып йому тизлегендә башкарырга булдылар.* Г. Минский.

КЫЗУЛАНУ *ф.* 1. Тизлекне арттыру; йөрешне тизләтү. *Иделнең салмак агымы кызулана төшкән туры[сыннан] узышлый, Гәрәй уйчан гына әйтеп куйды.* К. Нәҗми. *Бер сәгать тә, сәгать ярым да узып китте, полк шулай кызуланып баруында дәвам итте.* Г. Бәширов.

2. Ашыгу, кабалану. *[Закир] кушеткаңы аудара, һәр җирен кызуланып-кызуланып актара.* Г. Камал. || *күч.* Ярсу, ярсып китү, әсәрләнү. *Кызулана йөрәк ташкыны.* М. Җәлил. *Вәли кызуланып --- сугам дигәндә, Фәтхи --- тайпылып кала.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

3. Җанлану; көчәю, шәбәю. *Маневрлар әле яңа гына кызуланып бара башлады.* Һ. Такташ.

КЫЗУЛАТУ *ф.* Тизләтү, шәбәйтү. *Ул — атны кызулатканнан-кызулатты һәм бары тик эшлея кәешлары астындагы күбекләр күренә башлагач кына юыртудан туктады.* Р. Төхфәтуллин. *Борчулы уйлар Гришаның да аяк адымнарын кызулаттылар.* А. Әхмәт.

КЫЗУЛАУ *ф.* 1. Тизлекне арттыру; тиз бара башлау. *Ул, авылга кергәч, бабайны әйдәп, тагы да кызулый төште.* Г. Гобәй. *Машина тагын да кызулый башлады.* Г. Бәширов.

2. Ашыктыру, тизләтү. *[Сафура:] Бик кызулыйсыз, Ибраһим абзый. Чак кына утырып тын алырга ирек бирегез, ичмасам, әле яңа гына кереп җиттек лабаса.* Ш. Камал. *[Мария Петровна] хезмәт*

хакын нәкъ вакытында, билгеләнгән көннән калдырмыйча бирергә кызулый. И. Салахов.

3. *рәв. мәгъ.* **кызулап.** Тиз, шәп, ашыгып. *Карлыгач-сылу кызулап килеп керде.* Г. Ибраһимов.

КЫЗУЛЫК *и* **1.** Эсселек, эсселек дәрәҗәсе, югары температуралылык. *Бер сәгать кенә моннан элек явып киткән җиңел яңгыр --- һавадагы кызулыкны җиңелчә язгы җылылык белән алмаштырып, көнне ямьлелекнең чигенә ирештергән иде.* Ф. Әмирхан.

2. Тизлек. *Поезд урта кызулык белән бара.* Ә. Айдар. *Мостафа йөгерүгә якын кызулык белән чүмәләгә солы өемнәре ташый иде.* Ш. Камал. || Ашыгычлык. [*Шәмсия:*] *Бая кызулык белән сораша алмадым.* Т. Гыйззәт. [*Әнисе*], *үзе кинәт, әллә каян килгән кызулык белән шакмак ярырга, самовар куярга тотынды.* Ә. Фәйзи.

3. Нинди дә булса эшне тиз башкарырга омтылу, ашкынучанлык. *Яшьләр шунда ук суд ясарга хәзерләнделәр. Тик Петров кына аларның кызулыгын бераз сүрелдерде.* К. Нәҗми. *Карт урманчының бу сүзләре Газинурның кызулыгын беркадәр сүрелдерде.* Г. Әпсәләмов.

4. *күч.* Ярсу, ярсу тойгысы. *Теге кичне кызулык белән әйтеп ташлаган сүзләре өчен хәзер ул үзе дә ояла.* Г. Бәширов.

КЫЗ-ХАТЫН *җыйд. и. сөйл. к.* хатын-кыз. *Бу чуар публиканың тагын бер характерлы ягын әйтеп үтәргә кирәк: анда күпчелек—кыз-хатыннар.* Г. Гали.

КЫЗЧЫК *и. сөйл.* Кыз бала, кече яшьтәге кыз. *Кызчык, әнисен күреп, куана-куана йөгереп килде.* Г. Гобәй. *Безнең янга кечкенә кызчык йөгереп килде.* М. Әмир. || Яшүсмер кыз. *Әсма әле ул вакытта бишенче классның гимназисткасы, гаять яшь, мәңге хәрәкәтләнеп тора торган кызчык иде.* Ф. Әмирхан.

КЫЗЫГУ *ф.* **1.** Нәрсәне дә булса булдырырга теләү, аңа ия булырга омтылу. [*Вәли:*] *Зөләйха малга кызыкмаса кызыкмас, сүз юк. Әмма атасы кызыга шул.* Г. Коләхметов. || Теләү, нинди дә булса теләк уяну, күңел тарту. *Яз язу, ләкин кызыкма һич вакыт шөһрәткә син.* Г. Тукай. [*Фәридә:*] *Ә синең начальник буласың килде, авторитетка кызыктың.* Р. Ишморат.

2. Көнләшү, көнләшеп карау; көнчелек хисе туу. *Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем.* Г. Тукай. *Кызыкма байга, дуслык һәм Мәхәббәт юк аларда.* М. Җәлил.

КЫЗЫЙ *и. сөйл. фам.* Кыз кеше яки, гомумән, хатын-кыз турында беркадәр фамильярлык төсмере белән сөйләгәндә, яисә аңа мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. *Юк, бу кызый бүтәннәр салган сукмактан барырга гына риза түгел, ул абына-сөртенә, адаша-ялгыша булса да, үз сызыгы белән китәчәк.* Г. Бәширов. *Син, кызый, тирәнтен сукалый башлагансың.* Һ. Такташ.

КЫЗЫК *с.* **1.** Кызыксыну уята торган, кызыксындыра торган, игътибарны тарта торган; мавыктыргыч. [*Хәлим*], *ут кабызгач, сабагын хәзерли, яисә берәр кызык китап укый.* И. Гази. *Җитмәсә, кызык кына бер вакыйга да булып алды.* Г. Ибраһимов. | *рәв. мәгъ. Бу сүзләр Мохтарга кызык тоелды.* Ш. Камал. *Без малайлар өчен бу зур сәфәр әллә ничек кызык күренде.* Ш. Маннур. || *и. мәгъ.* Кызыксыну уята торган, күңелне җәлеп итә торган әйбер яки күренеш; кызыклы нәрсә. *Газизә апа Габдулланы җитәкләп әйләнчек яныннан китәргә җыенды, ләкин Габдулла бу искиткеч кызыктан аерыласы килми.* Ә. Фәйзи.

2. Көлкеле, көлдерә торган, мәзәк. *Кызык сүз әйтү.* □ *Казый абзый куйды шаркылдап көлеп, Гайрәте сүнде кызык эшне күреп.* Г. Тукай. | *рәв. мәгъ. Мәҗлес кызык барды.* Г. Ибраһимов. || *и. мәгъ.* Көлкеле нәрсә, көлкеле эш, көлдерә торган күренеш; мәзәк. *Баштан үткән кызыкларны искә төшереп, авылдагы хәлләргә, культура мәсьәләләренә, комсомол эшләренә дә кагылдык.* М. Әмир. [*Мирзахан:*] *Халык шулай инде ул, кызык күрәсе килә торгандыр.* Т. Гыйззәт.

3. *сөйл.* Үзенчәлекле, үзенә бер төрле; оригиналь. [*Зөлфия:*] *Кызык характерлы кыз бу Җәүһәрия.* Р. Ишморат. — *Иптәш Петрова, син кызык кеше икәнсең.* Т. Гыйззәт.

4. *и. мәгъ.* Берәр нәрсәнең яки эш-хәрәкәтнең кызыктыра торган ягы, үзенчәлеге. *Бу вакыйгадан соң миңа бәйрәмнең бер кызыгы да булмады.* Ф. Әмирхан. — *Картлар өчен урамда йөрүнең кызыгы бетте.* М. Фәйзи.

КЫЗЫКЛАНДЫРУ *ф.* **1.** *к.* кызыклату.

2. *сир.* Кызыксыну уяту, кызыктыру. [*Ул*] *үзенең --- материалының яшеренлеге белән арада аеруча кызыкландырган шаһитларның берсе булып чыкты.* Г. Ибраһимов.

КЫЗЫКЛАНУ *ф. сир.* **1.** Кызыклы күренешкә әйләнү, үзенә бер төрле кызык төс алу. *Безнең көрәш шушы сәю белән Кызыкланды, Үсте, Ямьләнде.* М. Җәлил.

2. *сөйл.* Кызык табу; мавыгу. *Кызлар аерым бер төркем булып күзгә бәреләләр. Алар нәрсә сөйләп кызыклана торганнардыр — белеп булмый.* М. Гафури. *Балаган янына барып, курчак сөйләгәнне тыңладылар һәм, кырыгынчы мәртәбә ишетүләре булса да, әүвәлге мәртәбәдәге шикелле кызыкландылар.* Ф. Әмирхан.

КЫЗЫКЛАТУ *ф.* Кызыклы итү; кызыклы итеп күрсәтү. *Моннан тыш бу каһарманнарның әсәргә кертелүе, сюжетны катлауландырып, хикәяләүне кызыклатуга да күп ярдәм иткән.* Г. Нигъмәти.

КЫЗЫКЛЫ *с. к.* кызык 1. *Кыз чагында мавыктыргыч та, кызыклы да, кайсы яклары белән куркыныч та күз алдына килә торган бу яңа тормышка* [*Нәфисә*] *бик тыныч килеп керде.* Г. Бәширов. *Син дә кызыклы сәяхәт хәлләрен ихлас берлә тыңларсың.* Г. Тукай. | *рәв. мәгъ. Балалар кебек йотлыгуы, бер сүзне бетерми икенчесен башлаулары ничектер кызыклы вә күңелле тоела иде.* Ш. Камал. || *махс.* Мавыктыргыч, мавыктыра торган. *Кызыклы физика.*

КЫЗЫКЛЫК *и.* Кызыксыну уята торган буду, гаҗәпкә калдыра торган булу, күңелне тарта торган булу; мавыктыргыч булу. *Вакыйганың кызыклыгы.* □ *Кырлай кызы Гөләнвәрнең искиткеч кыюлыгын сөйли торган бу хәбәр үзенең яңалыгы һәм кызыклыгы белән Габдулланы шаккатырды.* Ә. Фәйзи.

КЫЗЫКСЫЗ *с.* Кызыксыну уятмый торган; күңелне, игътибарны тартмый торган. *Булыр һәркемгә көз көннәр кызыксыз, Бөтен нәрсә күңелсез һәм дә шыксыз.* М. Гафури. | *рәв. мәгъ. „Кызыл чәчәкләр"дәге Гали тибы белән „Безнең көннәр"дәге Йосыф-жанны да бер-бере янына китереп куеп карау кызыксыз булмас.* Г. Нигъмәти. || Күңелгә ошамый торган, күңелсез; начар. *Кызыксыз хәл килеп чыгу.* □ [*Лутов:*] *Бүген шактый кызыксыз бер вакыйга булды.* Ш. Камал.

КЫЗЫКСЫЗЛЫК *и.* Кызыксыз булу. *Өстәл тирәсендәге халык әле генә тереклекнең мәгънәсезлеге, тормышның кызыксызлыгы хакында сөйләшеп бетереп торалар иде.* Ф. Әмирхан.

КЫЗЫКСЫНДЫРУ *ф.* **1.** Кемдә дә булса кызыксыну хисе уяту; кемнең дә булса уен, игътибарын тарту, җәлеп итү. *Аларны бигрәк тә* [*әйдүкнең*] *кызыл галстугы белән киемнәре кызыксындырды.* Һ. Такташ. *Бу сорау әүтәгеләрнең барысын да кызыксындырды.* Г. Минский.

2. Хуплап, ярдәм итеп кемдә дә булса берәр эш эшләргә, башкарырга, эш сыйфатын яхшыртырга теләк тудыру. *Кызыксындыру премияләре. Кызыксындыру чарасы.*

КЫЗЫКСЫНУ *ф.* Кем яки нәрсә турында да булса белергә тырышу; кемгә яки нәрсәгә дә булса игътибар итү. *Газинур газета укырга ярата һәм халыкара хәлләр белән кызыксына.* Г. Әпсәләмов. *Якуб кирпеч заводындагы хәлләр белән кызыксынды.* И. Гази. || *и. мәгъ.* Берәр кешегә яки нәрсәгә карата булган игътибар. *Хатны ул [Габдулла] бик зур кызыксыну белән йотылып тыңлады.* Ә. Фәйзи. *Әгәр Хәбибуллин кунагына игътибар беләнрәк караса, аның нинди тирән кызыксыну белән, никадәр исе китеп, үзенә карап торуын күрер - - - иде.* Ә. Еники.

Кызыксынган як — 1) *махс.* судта катнашучы яке якның берсе, дәгъвачы яки җавапчы; 2) *сөйл.* теге яки бу эштә, теге яки бу бәхәстә билгеле бер мәнфәгать күзәткән як.

КЫЗЫКСЫНУЧАН *с.* Нинди дә булса нәрсәне, хәбәрне һ. б. белергә тырышучы; һәр яңа нәрсә белән кызыксыну гадәте булган. *Нәфисә кечкенәдән үк бөтен нәрсә белән кызыксынучан, күп белергә, һәммә нәрсәне төпченергә яратучан дәртле бала булып үсте.* Г. Бәширов.

КЫЗЫКСЫНУЧАНЛЫК *и.* Кызыксынучан булу.

КЫЗЫКТЫРГЫЧ *с.* Нинди дә булса ягы белән кызыксыну уята торган, күңелне тарта торган; мавыктыргыч. *„Җир уллары“ның канунга каршы көрәшләре барып чыкмастай, көч җитмәстәй, ләкин кызыктыргыч бер эш кенә булып кала.* Г. Нигъмәти.

КЫЗЫКТЫРУ *ф.* 1. Нәрсәгә дә булса ия булу теләге тудыру. *Байлык белән кызыктыру.* □ *Һич кызыктырмый мине шәп файтоны һәм арбасы.* Г. Тукай. || Көнләштерү, көнләшү хисе уяту. *Ул аллы-гөлле зур резина туп күтәреп чыкмаган булса һәм аның белән бөтен малайларны кызыктырып уйнамаган булса, бернәрсә дә булмаган булыр иде.* А. Шамов.

2. Нинди дә булса берәр эшкә дәртләндерү, берәр эш башкарырга, үтәргә теләк уяту. *Солдат та, башка инптәшләре дә яңа килгән егетләрне мондагы эшкә кызыктыра һәм үзләре белән калырга димли иделәр.* Ш. Камал.

3. Кемдә дә булса берәр нәрсә белән кызыксыну хисе уяту; мавыктыру. [*Ишаннар*] *аларны, ожмах исемле бакчага алып барабыз дип, кызыктыралар.* Г. Тукай. *Рус театры мине бик кызыктыра башлады.* М. Гали.

КЫЗЫЛ *с.* 1. Салават күперендәге төп төсләрнең берсенә охшаган, саф кан төсендәге. *Кызыл чәчәк. Кызыл флаг.* □ *Авылның нәкъ үзәгенә урнашып ерактан күренгән бу кызыл түбәле йортларның берсе — узган ел салынып беткән җидееллык мәктәп.* М. Әмир. *Вафа кызыл күлмәк өстеннән каеш буган.* М. Фәйзи.

2. *сөйл.* Кызгылт көрән; кара кызыл (сыер, бозау төсе турында). *Кызыл сыер.* □ *Койма буендагы күләгәдә күшәп яткан зур кызыл бозау безгә әйләнеп тә карамады.* М. Әмир. || *сөйл.* дөрес кулланылмый. Туры (ат төсе). —*Кызыл бия белән күк алашаны теге зур чанага җигәрсең.* И. Гази.

3. Канның тирегә күбрәк килүе аркасында кызыл төс алган, беркадәр кан төсе кергән. [*Ситдыйкның*] *йөзләренә тимгел-тимгел булып кызыл таплар чыкты.* Ә. Фәйзи.

4. Виноград яки башка төрле җимеш суыннан әчетеп ясалган. [*Гайния:*] *Зәйни абзый сиңа кызыл белән ак аракының ике бутылкасын гына кушарга әйткән иде ич, э син барысын да кушкансың.* Ф. Бурнаш.

5. *күч.* Революцион көрәшкә катнашучы, революцион көрәш яклы; социалистик революциягә бәйләне шле. *Кызыл фронтовиклар.* □ *Ул тойгы аны Казанга килеп кергән кызыл отрядларның берсенә иярткән.* К. Нәҗми. || *иск.* Совет гаскәрләренә караган, Совет гаскәрләренә бәйләнешле. *Кызыл сакчы аргамагын Шул чишмәдән сугара.* М. Җәлил. *Тау башында кызыл кавалериянең күтәргән тузаннары гына күренә иде инде.* Ш. Усманов. || *сөйл. иск.* Совет социалистик төзелештә катнашучы, совет яклы. *Шуннан кызыл доцент исеме аңа биргәннәр.* Һ. Такташ. || Революцион, хак, дөрес. [*Каһарман:*] *Уземдә көч, күңелдә эш, тагын үткен кылыч кулда, Алырмын җан, түгәрмен кан шушы изге кызыл юлда.* М. Гафури. || *и. мәгъ. күпл. тар.* **кызыллар**—1) совет социалистик төзелеш яклы кешеләр, коммунистлар, революционерлар, революцион гаскәрләр. *Бөтен кырларны тутырып, штыкларны кояшта ялтыратып, кызыллар киләләр.* Һ. Такташ. *Якуп юлда туктап тыңлап торды: кемнәр аталар моны, аклармы, кызыллармы.* И. Гази; 2) Октябрь революциясенә кадәр: җәдитчеләр, җәдитчеләр яклы. *Тирә-яктагы берничә мөгаллим өстеннән ниндидер бер карт мулла: „Алар кызыллар, алар падишага каршы халыкны котырталар“, — дип әләкләгән.* Г. Ибраһимов.

6. XX йөз башында җәдитчеләр хәрәкәтендә катнашучы, җәдитчеләр яклы. *Кызыл яшьләрнең бер төркеме Гәрәй Солтанның теленә, кискенлегенә иярә башлыйлар.* Г. Ибраһимов.

7. *күч.* Һич тайпылмыйча билгеле бер карашны яклаучы, эзлекле тарафдар булган, ортодокс булган. *Әлхасыйль, бигрәк җәте кызыл мөэмин булып кылана.* Г. Тукай. [*Муса:*] *Без һәр адымыбызда артык дәрәҗәдә кызыл, чәчрәп торган ортодокс булып - - - кыланганладык.* Ш. Маннур. | *рәв. мәгъ.* [*Шиһапов:*] *Әгәр яңадан туып була торган булса, һәм без яшь чактагы өермәле еллар тагы кабатлана калса, мин - - - кызыл сөйли дип уйламагыз, мин тагын* [*стройдан*] *ике адым алга чыгар идем.* И. Гази.

8. Ботаника, зоология, минералогия һ. б. ш. фәннәр буенча кайбер тезмә терминнарның беренче сүзе булып килә. *Кызыл клевер. Кызыл элмә. Кызыл карлыган. Кызыл ярканат. Кызыл болан. Кызыл бүре. Кызыл якут. Кызыл лалә. Кызыл мәк. Кызыл солыча.*

Кызыл агач — 1) кызгылт үзагачлы көньяк агачы; 2) югары сыйфатлы агач әйберләр эшләү өчен кулланыла торган кыйммәтле агачларның үзагачы. [*Хәмидә:*] *Шкафы бик зур, бик әйбәт кызыл агачтан ясалган.* Г. Камал. **Кызыл Армия** *тар.*— Совет Армиясенең 1918 елдан 1946 елга кадәр булган исеме. *М. Гафури - - - бу әсәрләрендә илебезнең эшче-крестьян яшьләрен, Кызыл Армия сафларына басып, илне саклау өчен кискен көрәшергә чакырды.* М. Җәлил. **Кызыл байрак** — 1) революцион азатлык көрәшенең халыкара символы. *Барысы да - - - имәннең иң югары ботагына урнашкан кызыл байракка әйләнеп карадылар.* К. Нәҗми; 2) СССРда дәүләт флагы. *Халык өстендә Беренче май бәйрәмнәрендәге төсле дулкын-дулкын булып кызыл байраклар җилферди.* Г. Бәширов. **Кызыл Байрак ордены** — Советлар Союзы дошманнары белән көрәштә күрсәткән батырлык өчен Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез Флоты хәрби хезмәткәрләренә һәм аерым хәрби частьларга бирелә торган сугышчан орден. *Нурый Сәгыйтовка аклар белән көрәшүдә зур хезмәтләр күрсәтүе өчен Кызыл Байрак ордены бирелде.* М. Гафури. **Кызыл балык** — осетрлар семьялыгына керә торган балык (севрюга, белуга һ. б.). || Шул балыкның ите. [*Суыткычта*] *хәтта бер зур гына кызыл балык кисәге дә бар иде.* А. Расих. *Арслан кыйммәтле кызыл балык алып кайткан иде.* Г. Ахунов. **Кызыл бакыр** — башка металл катнашмалары булмаган саф

бакыр. *Берникадәр вакыттан соң пробиркада кызыл бакыр порошогы күренә башлый.* Химия. **Кызыл билет** *иск.* — революциягә кадәр хәрби хезмәткә каралган вакытта армиягә алынмыйча, ләкин бер айга хәрби хезмәтне өйрәнергә барып кайтырга тиешле кешеләргә бирелгән билет. *Кызыл билетка калганнарны, икенче төрле итеп, чабаталылар дип тә йөртәләр иде.* М. Гали. **Кызыл билетлы** *иск.* — революциягә кадәр бер айга хәрби хезмәтне өйрәнергә барып кайтырга тиешле, армиягә алынмаган кеше. — *Кызыл билетлылар, кырык яшькә чаклы берсе-бер калмыйча, иртәгә көтү куган вакытта Казанга чыгып китә.* Г. Бәширов. **Кызыл борыч** — 1) пасленчалар семьялыгыннан кызыл кузаклар бирә торган көньяк үсемлеге, кузаклы борыч. [*Ибрай:*] *Помидор кирәкме, кыяр кирәкме, кызыл борыч кирәкме, үстереп өлгертәбез.* М. Әмир; 2) шул үсемлекнең аш тәмләткеч буларак кулланыла торган ачы җимеше. [*Ике стаканның*] *берсенә күп кенә итеп төйгән кызыл борыч салып, кашык сабы белән бик ныклап буташтырган, Җиһангир картка тоттырды.* Ш. Камал. **Кызыл вагон** — йөк вагоны, товар вагоны. *Гаскәриләр кызыл вагоннарның эчендә - - - йоклаганнар.* Ш. Усманов. **Кызыл галстук** — пионерлар алдан төенләп бәйләп муенга тага торган өчпочмаклы кызыл яулык. *Кызыл галстуклы пионер.* **Кызыл гаскәр** *тар.* — 1) *к.* Кызыл Армия. *Хаклык алдын барчадан, Өстен барча нәрсәдән! Кызыл гаскәр көче берләп Өстен булды һаман.* М. Җәлил; 2) Кызыл Армия подразделениеләре. *Кызыл гаскәр өстенә - - - казаклар - - - һөҗүм иттеләр.* Ш. Усманов. **Кызыл гвардин** *сөйл.* — *к.* кызылгвардеец. *Д ул югалмаган, үлмәгән, Петроградта кызыл гвардин булып, патша төшереп йөри икән.* Г. Бәширов. **Кызыл гвардия** *тар.* — 1917—1918 елларда Октябрь кораллы восстаниесен үткәрү, Совет дәүләтен чит ил интервенциясеннән һәм эчке контрреволюциядән саклау өчен оештырылган кораллы эшчеләр отрядлары. *Кызыл гвардия частьларының банданың эзенә төшүе турында - - - хәбәрләр булды.* Г. Минский. **Кызыл гөмбә** *бот.* — урманда үсә торган аксыл кызыл эшләпәле гөмбә; *русчасы:* волнушка. *Пешермичә тозлау өчен җирән гөмбә (рыжик), нарат гөмбәсе (груздь), кызыл гөмбә (волнушка), ал гөмбә (сыроежка) алына.* Йорт эшләре. **Кызыл зәнбәкъ** *бот.* — лалә̆ләр семьялыгыннан кыңгырауга охшашлы эре кызыл чәчәкле үсемлек; *русчасы:* красная лилия. **Кызыл йолдыз** — барлык илләр хезмәт ияләренең бердәмлеге символы, биш канатлы йолдыз. *Аларның очлы башлы бүреклә̆рендә кызыл йолдызлар ялтырый.* Һ. Такташ. **Кызыл Йолдыз ордены** — СССРны саклауда күрсәткән аеруча зур батырлыклар өчен Совет Армиясе һәм Флоты хәрби хезмәткәрләренә, гаскәри частьларга бирелә торган хәрби орден. [*Җәүһәриянең*] *күкрәгендә Кызыл Йолдыз ордены да бар иде.* Г. Бәширов. **Кызыл каз** *и. зоол.* — тропикларда һәм субтропикларда яши торган, каурыйлары ал төстәге, озын муенлы һәм озын аяклы су кошы; *русчасы:* фламинго. **Кызыл кан тәнчекләре** *анат.* — канның состав өлеше, эритроцитлар. *Кызыл кан тәнчекләренең әһәмияте шунда ки, алар кислород күчереп йөртәләр.* Анатомия. **Кызыл карлыган** *бот.* — карлыганның бер төре, җиләге кызыл була. [*Галиулла:*] *Степанга барам да күп итеп кара карлыган, кызыл карлыган, кура җилләге куагы алып кайтам, читән буйларына утыртам.* И. Гази. **Кызыл корт** — эремчекне кызарганчы кайнатып, махсус ысул белән ясалган ашамлык. [*Зифа карчык*] *әлү кагын, пыяла савыты белән балын һәм кызыл корт белән аралаштырган маен алып кергәндә, Миңнур карт белән Шәрифулла, ашый-ашый, дусларча тыныч кына сөйләшәләр иде.* А. Шамов. **Кызыл корт төшү** — бодай өлгерә башлау (бу вакытта бодай бөртекләрендә вак кына кызыл кортлар күренә башлый). **Кызыл мал** *иск.* — тукымалар, мануфактуралар. [*Галимҗан:*] *Мин кызыл мал бүлегендә сәүдә итәм.* Т. Гыйззәт. **Кызыл малчы** *иск.* — мануфактура белән сәүдә итүче. *Авылга өч-дүрт йөк товар төяп кызыл малчылар килгән.* Г. Бәширов. **Кызыл мәче борчагы** *бот.* — мальвалар семьялыгыннан ал яки кызыл чәчәкле үсемлек; *русчасы:* просвирник лесной. **Кызыл обоз (олау)** — дәүләтнең ашлык җыю пунктларына ашлык тапшыру өчен крестьяннар-колхозчылар тарафыннан оештырылган, берсе артыннан берсе бара торган, кызыл флаглар тагылган берничә олау. [*Газинур:*] *Юл бирегез, икмәк төяп кызыл обозлар бара.* Г. Әпсәләмов. *Таң белән кызыл олаулар Кузгалыр ашлык төяп.* Ә. Исхак. **Кызыл почмак** — учреждение, тулай торак һ. б. урыннарда культура-агарту эшләре алып бару өчен махсус җиһазландырылган бина, бүлмә. [*Шәмсетдин карт:*] *Телә̆сә̆гез — театр куясыз, телә̆сә̆гез — кызыл почмакка кереп, гәҗит-журналлар укыйсыз, төрле уеннар оештырасыз.* А. Шамов. **Кызыл сыр** *иск.* — 1) кызыл төстәге минерал — күкертле терекөмеш; 2) шул минералдан алынган кызыл буяу. **Кызыл такта** *иск.* — иң алдынгы эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең исеме язылган яки рәсемнәре куелган такта, мактау тактасы. *Бригадасы дан күтәргән аның һәм төшмәгән кызыл тактадан.* Ш. Маннур. **Кызыл тал** *бот.* — үсеп чыккан вакытта кызгылт-көрән булган, таллар семьялыгына керә торган куаклык яки агач; *русчасы:* краснотал. **Кызыл таракан** — торак йортларда яши торган озын мыеклы кызыл төстәге бөҗәк. **Кызыл террор** *тар.* — эчке һәм тышкы контрреволюциянең дошманлык чыгышларын һәм сыйнфый дошманның каршылык күрсәтүен юкка чыгару өчен, революцион хөкүмәт тарафыннан күрелә торган чаралар. *Контрреволюция террорына җавап йөзеннән Совет власте кызыл террор кертте.* КПСС тарихы. **Кызыл товар** *иск.* — *к.* кызыл мал. **Кызыл туй** — Октябрь революциясеннән соң, дини йолалар урынына яңа йолалар белән үткәрелә торган туй. [*Галәк бабай:*] *Ягез, җәмәгать, табынны көттермик, колхозыбызның кызыл туе котлы булсын. Яшьләргә тигез гомер теликләр!* Г. Әпсәләмов. **Кызыл туфрак** — субтропик зонасына хас, составында тимер булган уңдырышлы туфрак. **Кызыл тәнле** — көньяк һәм төньяк Америкада яшәүче индеецларга карата әйтелә (индеецларны тәннәрен кызылга буяган өчен европалылар шулай атаганнар). **Кызыл тәре** *сөйл.* — *к.* Кызыл Хач. *Бер-бер артлы тезелеп киткән яшел вагоннарның стеналарында зур-зур кызыл тәреләр күренә.* Г. Гобәй. **Кызыл флот** — 1918 елдан алып 1946 елга кадәр Совет хәрби-диңгез көчләренең исеме. **Кызыл фонарь** *иск.* — фахешханә. *Ул гына да түгел — аны теге дөньяга, кызыл фонарьларга йөри имеш дип сөйлиләр.* Г. Ибраһимов. **Кызыл хан үләне** *бот.* — *к.* кырлыган. **Кызыл Хач** — Кызыл Хач җәмгыятенең эмблемасы — туры почмак ясап кисешкән ике тигез буйдан тора. *Госпиталь үзенең вакытлы чатырларын корып җибәрде, һәм яңадан аның кызыл хачлы ак флагы җилферди башлады.* Г. Әпсәләмов. **Кызыл Хач җәмгыяте** — сугыш вакытында авыруларга һәм яралыларга, табигать бәла-казалары вакытында медицина булышлыгына мохтаҗ булган барлык кешеләргә, шулай ук политик тоткыннарга ярдәм күрсәтү өчен оештырылган халыкара оешма. *Госман - - - Кызыл Хач җәмгыяте поликлиникасыннан доктор чакырды.* А. Шамов. **Кызыл черек** *бот.* — наратта үсә торган ку гөмбәсе. **Кызыл эремчек** — *к.* кызыл корт. **Кызыл эшелон** — йөк поезды, товар поезды. *Менә станциянең платформасы күренде. Аның алдында кызыл эшелон тора.* Ә. Еники. **Кызыл**

юл — 1) абзацның тоташ тексттан бераз эчкә керебрәк башланган юлы; 2) *тип.* кәгазь битенең уртасына басыла торган баш юлы. **Кызыл якут** *мин.* — кызыл төстәге кыйммәтле асылташ. *Бирма кызыл якут чыгаруда дан тота.* Чит ил. экон. географиясе. **Кызыл ярты ай** — Кызыл ярты ай җәмгыятенең эмблемасы, кызыл төстәге ярты ай рәвешендә була. **Кызыл ярты ай җәмгыяте** — кайбер Көнчыгыш илләрендә функциясе Кызыл Хач җәмгыятенеке кебек булган җәмгыять. **Кызыл әләм** *иск.* — *к.* кызыл байрак. *Кызыл әләм илдән өскә чыгар, Бөтен илгә күренеп ялтырар.* М. Җәлил. **Кызыл үңәч** *диал.* — кешедә һәм хайваннарда азык кайнату трактының авыз куышлыгыннан алып ашказанына кадәр булган өлеше.

◇ **Кызыл авыз** — 1) *иск.* XX йөз башында кадимчеләр тарафыннан җәдитчеләргә, җәдитче яшьләргә карата кимсетеп әйтелгән сүз. [*Шкафчы:*] *әдәбият кичәсе имеш! Анда авыз күтәреп җырлыйлар, ди, сөйлиләр, ди. Җыен кызыл авызлар чыгып скрипка, гармонь уйныйлар, ди.* Г. Камал; 2) *иск.* революция дошманнары тарафыннан большевикларга, кызыл сугышчыларга, гомумән, Совет властен актив яклаучы кешеләргә карата мыскыллап әйтелгән сүз. [*Камали:*] *Кара син аларны, замана фетнәләрен, ә - - - хәмсәмул булганнар, имеш. Кая качтылар әле үзләре - - - Бирермен мин сезгә - - - кызыл авызлар!* Ф. Бурнаш; 3) бик яшь, тәжрибәсез яки юньсез, телмәкәр кеше турында. *Бу Казан кунагы ниндирәк кеше икән? Мужикның хәленә кererлекме, әллә кызыл авыз гыкамы?* И. Гази. **Кызыл камыт кидерү (кию)** *әвф.* — сую, бугазлау (терлек турында). [*Яшь көтүче әйдүк:*] *Авылга аклар килсә, кызыл камыт киясегезне белмисезмени, — дип сөйләнеп маташса да, сыерлар авылга аклар киләсен, килгәч аларга уңайсыз буласын аңларга теләмәделәр.* Һ. Такташ. **Кызыл кар яугач (яуганда)** — бервакытта да, беркайчан да, һичкайчан да (булмаячак эш турында). [*Мортаза*] *йөз тәңкәне, кызыл кар яугач түләрмен дип, бик зур догалар укып, сакалларын селкетеп алган дип сөйлиләр.* Г. Тукай. **Кызыл кәгазь** *сөйл.* — революциягә кадәр ун сумлык кәгазь акчаны шулай йөрткәннәр. *Ул хәзрәткә бер кызыл кәгазьне һәйбәтләп яудырырга кирәк.* Г. Ибраһимов. **Кызыл күлмәк кидерү (кидертү)** *гади с.* — сую, үтерү (кешене). *Берсе Хәлимгә пычак күрсәтеп китте: „Кара аны, студент, безнең кызлар янында бик чуалсаң, кызыл күлмәк кидертәрбез!" дип, пычагы белән мәгънәле генә селтәнде.* И. Гази. **Кызыл әтәч** — янгын. *Кайсы чиләк, кайсы көрәк-лом белән коралланган кешеләр утка каршы һөҗүмгә ташландылар. Ләкин „кызыл әтәч" алай тиз генә бирешергә теләмәде.* Соц. Тат. **Кызыл әтәч җибәрү** — ут төртү, яндыру (күбрәк яшертен рәвештә ут төртү турында әйтелә). — *Каршы тора башласа, сарайларына кызыл әтәч җибәрәбез.* Г. Ибраһимов. **Кызыл үгездән сөздерү** — 1) яндыру. [*Бигәш:*] *Сөздерик кызыл үгездән [шүрәлене] — тотыйк та салыйк утка.* Д. Гобәйди; 2) ришвәт бирү; аракы эчерү. **Кызыл җеп булып сузылу** — төп идея булып аерылып тору, төп идея итеп чагылдырылу. *Хезмәт ияләренең, халыкның язмышы өчен яну [М. Гафури] иҗатының буеннан-буена кызыл җеп булып сузылып барды.* Х. Хисмәтуллин.

КЫЗЫЛАРМЕЕЦ *и.* Кызыл Армия сугышчысы, гаскәри. *1918 елны гражданнар сугышы вакытында җиде кызылармеец, шул йортка бикләнеп, көннең-көн буена үзләрен камап алган ак бандага каршы торалар.* Г. Гобәй. *Агым суда кызылармеец Атын юл.* М. Җәлил.

КЫЗЫЛБАШ I *и. бот.* Гөлчәчәкләр семьялыгыннан күпьеллык дару үләне; *русчасы:* кровохлебка. *Мондый болыннарда ак һәм ал клевер, болын күкчәчәге, кузгалак, эт какысы, кызылбаш - - - тычкан борчагы һәм башка күп кенә үләннәр үсә.* Умартачылык.

КЫЗЫЛБАШ II *и. иск. тар.* Фарсы, фарсы кешесе, иранлы. *Мәскәү һәм Варшава фабрикантлары һәр елны - - - әрмәннәр илә кызылбашларга - - - көтәсегә ничә миллионлык мал саталар.* Ш. Мөхәммәдев.

КЫЗЫЛБАШ III *и. сөйл.* Шешә авызы кызыл сургуч белән печатьләнгән аракы. *Бер чирек әче бал белән бер бөтен кызылбашны кургәч, картларның авызлары колакларына җитте, күзләре уйный башлады.* Г. Ибраһимов. *Яшьләр шул арада чирекле кызылбашны кайтарып та өлгергәннәр икән.* Г. Бәширов.

КЫЗЫЛГВАРДЕЕЦ *и. тар.* Кызыл гвардия сугышчысы, гаскәрие. *Хәзер инде кызылгвардеецлар да, Данилов батареясе дә Ксения артыннан Кремль стенасына таба киттеләр.* К. Нәжми.

КЫЗЫЛГВАРДИЯЧЕ *и. к.* кызылгвардеец.

КЫЗЫЛКАНАТ *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан төче суда яши торган кызыл канатлы балык; *русчасы:* красноперка. [*Гыйльманов:*] *Кызылканат һәм алабугалар төкерек исенә киләләр.* Ш. Камал.

КЫЗЫЛКОЙРЫК *и. к.* уткойрык; *русчасы:* горихвостка.

КЫЗЫЛ КӨРӘН *с.* Беркадәр кызыл төскә тартым көрән, кызгылт көрән. *Аның җилдән, салкыннан, кояштан кызыл көрән төскә кергән йөзе, зур кара күзләре рухланып, балкып тора.* Г. Әпсәләмов.

КЫЗЫЛКҮЗ *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан төче суда яши торган кызыл күзле балык; *русчасы:* красноглазка.

КЫЗЫЛЛАНДЫРУ *ф. сөйл. к.* кызыллату.

КЫЗЫЛЛАНУ *ф.* 1. Кызыл төс керү, кызылга әйләнү; кызару. *Бакчадагы кызыл чәчәкләр, җылы яңгырлардан соң, якты, кояшлы аяз көннәрдә ничек матураеп, кызылланып, янып китсәләр, хәзер Гайния дә шулай булды.* Г. Ибраһимов. || Кызыл булып күренү. *Кадалды ук йөрәгемнең түренә, Кызылланып, җәрәхәттән кан ага.* М. Җәлил.

2. *куч. сөйл.* Сул карашлыга, алдынгы карашлыга әйләнү, карашлары суллану; хаклык, дөреслек юлына басу, прогресс юлына басу, революцион юлга басу (революция дошманнары кешеләрнең революция, хаклык юлына басуын шулай дип йөрткәннәр). [*Гыйният улла*] *бу вакыт эчендә сәяси яктан хәзер шактый ук суллашты, кызылланды.* С. Җәләл. [*Сөләйман:*] *Ә син алай артык кызылланып маташма!* Һ. Такташ.

КЫЗЫЛЛАТУ *ф.* Кызыл төскә кертү, кызарту, кызылландыру. *Күкне кызыллатып көн батуын, җәйге таң атуын яратам.* Ә. Ерикәй.

КЫЗЫЛЛЫ *с. иск.* Кызыл, кызыл төстәге, кызыл төс катнашкан. *Кызыллы күлмәк өстеннән яшелле алъяпкыч япкан кызның, үзенчә, купшы итеп, кәзкәз басыбрак барышында да бу күңеллелек сизелгән шикелле булды.* Ф. Әмирхан.

КЫЗЫЛЛЫ-ЗӘҢГӘРЛЕ *с.* Кызыл белән зәңгәр катнашкан төстәге. *Кызыллы-зәңгәрле күлмәк.*

КЫЗЫЛЛЫК *и.* 1. Кызыл булу; кызарган булу. [*Мавия:*] *Күзләремнең кызыллыгы аны күңелсезләр.* М. Фәйзи. *Болытның кызыллыгы тигез су өстенә ал шәүлә булып төште.* И. Гази.

2. Кояш баткан яки чыккан чакта күк гөмбәзе горизонт янында балкудан барлыкка килгән кызгылт төс. *Тышта көнбатыштагы кызыллык бетеп җитмәгән булса да, йолдызлар белән бизәлгән җәйге төн урнашкан иде.* М. Әмир. || Янгынның, көчле атышның күктә чагылуыннан барлыкка килгән кызгылт төс.

3. Тәндәге кызыл тап, канның тирегә күбрәк килүе аркасында барлыкка килә торган кызыл төс. *Битләреңдә уйный Кызу эшләп Арганлыктан туган кызыллык.* М. Җәлил. *Гали абзыйның ябык һәм авырудан бераз саргая төшкән йөзенә кызыллык йөгерде, йомшак сары күзләре чак кына каралгандай булды.* Г. Әпсәләмов.

КЫЗЫЛЛЫ-КАРА(ЛЫ) *с.* Кызыл белән кара катнашкан төстәге. *Бәйрәм вә кунак кешеләре кызыллы-кара вә күк алачалардан.* З. Бәширн.

КЫЗЫЛЛЫ-КҮКЛЕ *с.* Кызыл белән күк катнашкан төстәге.

КЫЗЫЛЛЫ-САРЫЛЫ *с.* Кызгылт сары, кызыл катнашкан сары. *Кояш иңешендә, биек вә калын агачлар арасыннан гына кызыллы-сарылы офык күренә иде.* Ш. Камал.

КЫЗЫЛЛЫ-ЯШЕЛЛЕ *с.* Кызыл белән яшел катнашкан төстәге. *Кәкре койрыклы, балаклы, кылыч кикрикле, кызыллы-яшелле салават күпере төсле әтәчне, чырылдатып, күтәреп чыктылар.* М. Гали.

КЫЗЫЛСУ *с. кимл. дәр. к.* кызыл. *Гөлҗамал - - - кызылсу төстә*[ге] *ситсыларны туздырып ташлый.* Г. Ибраһимов.

КЫЗЫЛТАМЫР *и. бот.* Тамыры кызыл булган үләнчел үсемлек; *русчасы:* кузьмичева трава.

КЫЗЫЛТҮШ *и.* Чыпчыклар отрядыннан түше кызыл, зур булмаган сайрар соры кош; *русчасы:* зяблик. *Тәрәзә артында тынмас төн кошы — кызылтүш сайрап куйды.* Р. Төхфәтуллин. *Күкшәкош, кызылтүш, миләш чыпчыгы бик еш килде хәзер урманнан.* Г. Гобәй.

КЫЗЫЛФЛОТЧЫ *и. иск.* Кызыл флотта хезмәт итүче. *Кыю кызылфлотчы.*

КЫЗЫЛЧА I *и.* **1.** *мед.* Чирләгәндә кызыл тимгелләр, бөрчекләр чыга торган йогышлы авыру, беркадәр кызамык авыруын хәтерләтә (гадәттә, балаларда була); *русчасы:* краснуха. [*Әбүзәр:*] *Дифтерия, кызылча һәм башка шуның ише йогышлы чирләр белән авыручылар янына курыкмыйча баручы иң гади практик врачка кадәр һәммәсе батырлык күрсәтте.* Г. Әпсәләмов.

2. *махс.* Дуңгызларда була торган йогышлы авыру; *русчасы:* краснуха.

3. *с. мәгъ. иск.* Беркадәр кызыл, кызгылт.

КЫЗЫЛЧА II *и. бот.* **1.** Көньякта үсә торган сары чәчәкле куакчыл үсемлек.

2. Шул куаклыкның бик әче карасу кызыл җимеше (ашаганда авызны камаштыра).

КЫЗЫЛҖИМЕШ *и.* Кызылча куаклыгының җимеше.

КЫЗЫНУ *ф.* Үзеңне, үзеңнең тәнеңне җылыту; җылыну (мич, учак һ. б. ш. янында). *Мин, гөрләп янган саламга кызынып, мич каршында утырам.* Г. Ибраһимов. *Митричев, иреннәрен пешерә-пешерә тәмәке төпчеге суырып, лежанка миче каршында кызынып утыра.* Г. Бәширов. || Тәнне кояш нурлары тәэсире астына кую; тәнне кояш нурларында кыздыру. [*Кешеләр*] *Кара диңгезнең ягымлы һаваларын иснәп, көньякның көләч кояшында кызынырга баралар.* Ш. Камал.

КЫЗЫШТЫРУ *ф. сөйл.* Берәр эшкә дәртләндерү, дәрт-теләк уяту. *Ул да булмады, Хафизулла бу эшкә кемнәрнедер кызыштырырга теләп кычкыра башлады.* Г. Минский.

КЫЗЫШУ *ф.* **1.** Эсселәнү, кызу; температура күтәрелү (организм, тән турында). *Өенә кайтып җитәр-җитмәс,* [*Тимеринең*] *бөтен тәне уттай кызыша башлады.* Г. Бәширов. *Зәйтүнә авылга кайтып төшкән беренче көннәрне авырып, кызышып үткәрде.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Ярсу, ярсып китү, кызып китү. *Малайлар тәмам кызыштылар: „патшаның" башына, күкрәгенә, аркасына шап-шоп бомбалар ява башлады.* И. Гази. *Кызышкан малайлар, аның әрнеп елавына карамастан, күмәкләшеп, буталышып сугышларын дәвам иттерделәр.* М. Гафури.

3. *диал.* Юешлектән, дымлылыктан җылынып чери башлау, черү (ашлык турында).

КЫЙ I *и. диал.* Тизәк, коры тизәк. *Кый түгү.* □ *Мал кый белән, кунак сый белән.* Әйтем.

Кый үләне — җитен арасында үсә торган кузаклы чүп үләне.

КЫЙ II *кис. диал.* „Ич", „бит". *Базарларга бардым кый, Сары яулык алдым кый, Чакырдым кый, килмәдең кый, Җаннарымны кыйдың кый.* Җыр.

КЫЙБАТ *с. сөйл.* **1.** Югары, зур бәяле; кыйммәтле; *киресе:* арзан. *Ләкин китапның техникасы бик начар эшләнүне һәм китапка бик кыйбат хак куелуны бастыручыларның гаебе итеп күрсәтергә кирәк.* М. Җәлил. [*Чәй-шикәр*] *бик кыйбат булганга, минем кесәмне шактый бушаткан иде.* Г. Тукай. || *рәв. мәгъ.* Югары бәяне, югары бәягә, югары бәядән, югары хакка. — *Кайсыдыр Маликка каты бәйләнгән: нигә - - - син шырпыны, кәрәчинне, тозны шул хәтле кыйбат сатасың?* И. Гази.

2. *күч.* Әһәмиятле, мөһим, кадерле. *Авыл кешесенең, беләсең бит, җәй көнендә минуты кыйбат.* Ш. Камал. || Кадерле, газиз. *Һәркемнең башы үзенә кыйбат.* Г. Тукай. *Бу тавыш Гафур өчен дөньядагы бөтен музыкалардан, бөтен моңнардан кыйбат.* К. Нәҗми.

◇ **Кыйбат алмау (сорамау)** — теге яки бу эшне эшләргә әзер булу, әзер тору. [*Шәмсетдин:*] *Арт сабагыңны тыңлатырга хәзер дә кыйбат алмам.* А. Шамов. — *Тегеләр кайткан чакта, караңгыда берәрсен пешереп алырга да ул кыйбат сорамас, шулай түгелме?* Ш. Камал. **Кыйбат(ка) төшү** — *к.* кыйммәт(кә) төшү. *Әмма бу җиңүләр миңа бик кыйбат төшкән чаклар да булды.* Г. Ибраһимов. **Кыйбат түләү** — кирәген алу, җәзасын күрү. [*Ачы:*] *Бу эш өчен, ул бүреләр Кыйбат түләрләр, Җавап бирерләр баш белән һәм кан түгәрләр.* А. Алиш.

КЫЙБАТЛАНУ *ф.* Хакы (бәясе) күтәрелү, кыйммәтләнү. *Бара-бара безнең үз товарыбыз да кыйбатлана башлый.* Г. Тукай. [*Әхмәт:*] *Хәзер бит, үзегезгә мәгълүм, чәйләр кыйбатланды.* Г. Камал.

КЫЙБАТЛЫ *с.* **1.** Югары бәяле, хакы, бәясе югары; кыйммәтле. — *Тапкан әйберне һәрвакытта да хуҗасына кайтарып бирергә кирәк. Кыйбатлы әйберме ул, арзанлы әйберме — барыбер.* А. Шамов. *Башта Миңлебикәнең күзенә ягымлы күренгән адвокат көмеш савытыннан кыйбатлы папиросын чыгарып авызына капты.* К. Нәҗми.

2. Зур чыгым сорый торган. [*Әхмәтҗан:*] *Ходайга шөкер, кыйбатлы туйдан котылдым.* Г. Камал.

3. *хәб. функ.* Әһәмиятле, мөһим, кадерле. *Сиңа - - - Эшсез чуалуы кыйбатлы.* М. Җәлил.

КЫЙБАТЛЫК *и.* Кыйбат булу, югары хаклы булу; кыйммәтлек. *Бердән, моңа эш көчләренең кыйбатлыгы сәбәп булса, икенчедән, көзге налог һәм башка төрле салым вакытларында авыл ярлыларының аның канына тоз салулары да сәбәп иде.* А. Шамов.

КЫЙБАТЛЫЛЫК *и. к.* кыйбатлык.

КЫЙБАТСЫНУ *ф.* Кыйбатрак дип табу, кыйбатрак дип санау. *Сукыр Исмәгыйль белән Әсфәндияр акча-*

лата утыздан кимгә риза булмыйлар, җәмәгать аны кыйбатсына. М. Гали.

КЫЙБАТЧЫЛ *с.* Артык кыйбат сорый торган. *Кыйбатчыл кеше.*

КЫЙБАТЧЫЛЫК *и.* Товарларга һәм азык-төлеккә бәяләрнең бик югары булуы. *Хәл кискенләште. Илне кыйбатчылык каплады. Икмәк юк.* Х. Садрый. [*Карт*] *кыйбатчылыктан зарланып язган.* Ш. Камал.

КЫЙБЛА *и. иск.* 1. Мәккәгә караган як; намаз укыганда мөселманнарның йөз белән торган ягы. *Исмәгыйль хажи, азапланып, намаз укый торган паласын җәйде дә, йөзен кыйблага юнәлдереп, кулын һавага, йолдызларга таба күтәреп кычкырды.* Г. Тукай.

2. Көньяк. *Өйләгә таба авылның кыйбла як башындагы зур чирәмгә сабан туе өчен мәйдан ясыйлар.* Г. Ибраһимов. *Кыйблаларга очкан аккошларның Карап тордым тезелеп үтүен.* Җыр.

3. *күч.* Кешеләрнең күңелен тарткан нәрсә (урын); нәрсәнең дә булса үзәге. *Хәзер СССР булып әверелде Бөтен җир шарының кыйбласы.* М. Гафури. || Кемнең дә булса яраткан кешесе, күңелен үзенә тарткан кеше. [*Таһир:*] *Тапшырыгыз, гидай исәр җилләр, сәламемне Зөһрәм, кыйблама.* Ф. Бурнаш.

КЫЙБЛАНАМӘ *и. иск.* Компас. *Ярты сәгать үткәндә без инде, кыйбланамә белән турылап, пароходыбызны юлга салып өлгергән идек.* Ф. Әмирхан. [*Ш. Бабич*] *кайбер вакыт койрыкчысыз, кыйблананамәсез диңгезнең көчле дулкыннары арасына ташланган ялгыз көймә кебек, авыр мәшәкатьләр, газаплар чикте.* Г. Ибраһимов.

КЫЙГАЙТУ *ф. сөйл. к.* кыегайту. *Фәрит, учын кыйгайта төшеп,* [*өн тишеген*] *иптәшләренә күрсәтте дә тагын шап итеп томалап куйды.* Г. Гобәй.

КЫЙГАҠ, КЫЙГАК-КЫЙГАК *авазияр.* 1. Казларның, аккошларның кычкыру тавышын белдерә. *Кыйгак-кыйгак каз кычкыра Бер бәбкәсе юк өчен.* Г. Тукай. *Каңгылдашып баш очымнан казлар очты: „Кыйгак-кыйгак!“* С. Сөләйманова.

2. *с. мәгъ. сөйл.* Кыйгаклаучы, кыйгылдаучы. *Кыйгак казлар, Кыйгак казлар, Бармыйсызмы безнең якка?* Әкият.

КЫЙГАКЛАУ *ф.* Өзек-өзек авазлар чыгарып кычкыру (гадәттә казлар турында). [*Хәдичә түти*], *җилтерәтеп кенә чыгып, сыерын ябып, юынып керде, каты кыйгаклап баскычтан менеп килгән ата казны куып төшерде.* Г. Бәширов.

КЫЙГАЧ *с.* 1. Авыш, кыек, авыш булган, кыек булган. *Кичке кояшның тәрәзә аша төшкән кыйгач нурлары аның битен - - - бакыр төсенә кертеп яктырталар.* К. Нәҗми. || *рәв. мәгъ.* Туры юнәлешкә почмак ясап, кыек итеп. *Маякчы хатын, көймәнең борынын зур осталык белән агымга кыйгач тотып, ишә башлады.* Г. Гобәй.

2. Кошларның формасы ягыннан геометрик почмакны хәтерләткән кыйгач сафы.

3. *сөйл.* Өлге, клин. *Аклы ситсы күлмәгемнең итәге алты кыйгач.* Җыр.

4. *шигъ.* Дугаланып торган, кыйгачланып торган (кашлар турында). *Зифа буйлы, кыйгач кашлы, зәңгәр күзле длфия, Миңнурыйның киресе буларак, бик оялчан иде.* Г. Әпсәләмов.

КЫЙГАЧЛАНУ *ф.* Дугалану, дуга рәвешен алу, кәкре сызык рәвешен алу. *Аның сул күзенең өсте маңгай аркылы кыйгачланып сыдырылган.* Ә. Фәйзи.

КЫЙГАЧЛАУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса билгеле бер яссылыкка карата кыек итеп ясау, кыек итеп эшләү. *Шәкертләр чапаннарын киеп алдылар һәм чалмаларын „мысырча“ кыйгачлап урадылар.* Ә. Фәйзи.

2. Нинди дә булса туры юнәлешкә карата кыек хәрәкәт итү, кыек бару. [*Бикмүш бабай:*] *Алай текә кыйгачлама. Агым уңаенарак.* Г. Гобәй.

3. *рәв. мәгъ.* **кыйгачлап.** Берәр яссылыкка билгеле бер авышлык ясап; кыеклап. *Соңгы аэропортка Без кыйгачлап килеп төшкәндә — Мәскәү халкы ап-ак карда йөри.* М. Җәлил. [*Зөлфия*] *үзәнлекне кыйгачлап үтеп үргә күтәрелә.* Г. Әпсәләмов.

КЫЙГАЮ *ф. сөйл. к.* кыегаю. *Җил белән бераз кыйгайган чалмасын төзәткәннән соң,* [*Кари әфәндә*] *халыкның җөмләсенә бердән карап сөйләп китте.* Ф. Әмирхан.

КЫЙГЫЛДАШУ *ф. к.* кыйгаклау. *Киек казлар кыйгылдаша Мин белмәгән телләрдә.* Х. Туфан. *Инеш буенда кыйгылдашып казлар сугыша.* Э. Касыймов.

КЫЙГЫЛДАШУ-ЧИАКЛАШУ *ф. сөйл.* Өзек-өзек авазлар чыгарып кычкыру (казлар турында). *Казлар - - - кыйгылдаша-чиаклаша читкәрәк тайпылырга мәҗбүр булдылар.* Р. Төхфәтуллин.

КЫЙГЫР *и. диал.* Урманда яши һәм яңгыр алдыннан кычкыра торган кечерәк кош; яңгыр теләнчесе; *русчасы:* чеглок.

КЫЙКУЛАУ *ф. диал.* Каты кычкыру, төрле тавышлар чыгарып кычкыру. *Нигә алай кыйкулыйсың?*

КЫЙКЫЛДАУ *ф. сөйл.* 1. *к.* кыйгаклау. *Сарык тавышына каз кыйкылдаулары, тавык кыткылдаулары кушыла.* Г. Гобәй.

2. *диал.* Очкылык тоту.

КЫЙЛАНМЫШ *и. иск. к.* кыланыш. *Бу хатынның соң дәрәҗәдә мәшәкать вә михнәттә торганы кыяфәтеннән, кыйланмышыннан мәгълүм, үзе күтәрә алмаслык кайгыларны йотарга тырышканы хәрәкәт вә күзләреннән билгеле иде.* М. Гафури.

КЫЙЛАНУ *ф. сөйл. к.* кылану. [*Мөгълифә:*] *Матур кешеләр һәрвакытта да шулай инде алар, синең шикелле кыйланган булалар.* Г. Камал. [*Бәдри:*] *Катышкан кешең бай булгач, сиңа да азрак кешечә кыйланмый туры килми.* М. Фәйзи.

КЫЙЛАНЧЫК *с. иск. сөйл. к.* кыланчык [*Гыйльманов:*] *Шул инде, үзе, Абаев дигән кыйланчык.* Ш. Камал.

КЫЙЛАНЫШ *и. иск. сөйл.* 1. *к.* кыланыш. *Бабаларының кыйланышлары вә - - - Миңсылу абыстайның шушы ике-өч сәгать эчендә эшләп өлгергән эшләре хәзер аларны теге романнарда язылган нәрсәләргә ышанырга мәҗбүр итә башладылар.* Ф. Әмирхан.

2. *күч. иск., сөйл.* Хәл; гореф-гадәт. [*Күгәрчен:*] *Мин - - - кай җирдә нинди гаҗәпләр күргәнемне һәм кайда нинди гадәтләр, нинди кыйланышлар барлыгын сиңа хикәят итәрмен.* Г. Тукай.

КЫЙЛАУ *ф. диал.* Тизәкләү, тизәк түгү (басуга).

КЫЙЛУ *ф. иск. к.* кылу. *Суд, шөбһәсез, минем файдама эш кыйлыр дип, Галиәкбәр агайның өмите зур иде.* Ш. Мөхәммәдев.

КЫЙМАУ *ф.* Нинди дә булса эшне эшләргә яисә билгеле бер карарга килеп хәрәкәт итәргә батырчылык итмәү, кыюлык җитмәү. *Ләкин хуҗага каршы көрәш башларга ничектер кыймыйдыр иде.* К. Нәҗми. *Класс сулыш алырга кыймый тын калды.* Ә. Фәйзи.

КЫЙММӘТ *с.* 1. Югары бәяле, зур бәяле; югары (бәя турында); *киресе:* арзан. *Кыйммәт хаккa сату.* □ [*Франциядә*] *әйбер бәясе сугышка чаклыга караганда 4—5 тапкыр кыйммәт.* Г. Гали. || *рәв. мәгъ.*

Югары бәягә (бәядән, бәяле), югары хакка (хактан, хаклы). [*Бай:*] *Налогның зыяны һич безгә булмый: аның өчен мин товарны кыйммәт сатам.* М. Гафури.

2. *и.* Билгеле бер әһәмияткә ия булу, нәрсәнең дә булса әһәмияте, мөһимлеге. *Шигырьнең кыйммәте нәни бер идеяне кеше аңламаслык итеп язуда түгел.* Һ. Такташ. *Үзагачта ботаклар никадәр азрак булса, үзагачның кыйммәте шулкадәр югарырак икән.* Г. Әпсәләмов. || *күч.* Кадер, бәя, тоткан урын. [*Давыт:*] *Сандугач тавышын ишетеп, аныңча сайрарга азапланган чыпчыклар төсле, без дә дөньяда үзебезнең кыйммәтне аңламый яшибез.* Г. Коләхметов. *Тукай җәмгыятьтә кешенең авторитеты һәм кыйммәте булуны күрергә теләде.* Г. Халит.

3. *и. мат.* Математик зурлыкларның эчтәлеге, мәгънәсе. *Кыйммәтләрен үзгәртмичә саклый торган зурлыклар даими зурлыклар дип аталалар.* Алгебра.

4. *и. экон.* Товарны җитештерү өчен билгеле бер микъдарда сарыф ителгән абстракт хезмәт. *Кыйммәт — товар җитештерүчеләрнең товарда әйберләшкән иҗтимагый хезмәте ул.* Политэкономия.

Кыйммәт законы *махс.* — товар җитештерүнең экономик законы. Бу закон буенча товарлар алмашу аларны җитештерүгә киткән иҗтимагый зарур хезмәт чыгымнары нигезендә тормышка ашырыла. *Хосусый милек хөкем сөргәндә кыйммәт законы котылгысыз рәвештә капиталистик мөнәсәбәтләр, эксплуатация мөнәсәбәтләре тудыра.* Политэкономия.

◇ **Кыйммәт алмау (сорамау)** — *к.* кыйбат алмау (сорамау). **Кыйммәт(кә) төшү** — 1) күп акча чыгарырга туры килү. — *Беләсезме, алар* [*никрутлар*] *халыкка нинди кыйммәткә төшәләр.* Г. Ибраһимов; 2) *күч.* авырга туры килү (авыр кичерешләр белән бәйләнгән, күп көч, энергия сарыф итәргә туры килгән хәлләр һәм, гомумән, авырлыклар турында әйтелә). *Алай да бу* [*Пушкинның бер томлыгы*] *аңа бик кыйммәткә төште: ул ике атна, коры чәй эчеп, ачлы-туклы йөрде.* Ә. Фәйзи. **Кыйммәт түләү** — нәрсәне дә булса бик нык теләү, берәр нәрсәгә ирешергә бик нык омтылу турында. *Хәзер бу урында мин алар белән, ул ике иптәш белән сөйләшер өчен бик кыйммәт түләр идем.* Ш. Камал.

КЫЙММӘТДАР *с. иск. к.* кыйммәтле. *Саф вә мәгъсум балалык, - - - кыйммәтдар сабыйлык дәвере - - - иланһи бер күренеш шикелле узып китә.* Г. Ибраһимов.

КЫЙММӘТЛЕ *с.* **1.** Югары бәяле, бәясе югары; кыйбатлы. *Мусин, - - - кыйммәтле фаэтонга утырып, халыкны шаккатыру өчен базарга чыга.* Г. Тукай. *Рәхимовларның залында кыйммәтле рояль тора.* Ф. Әмирхан.

2. *махс.* Бәясе, хакы күрсәтелгән; бәяле. *Кыйммәтле хат* (бәясе күрсәтелгән хат). *Кыйммәтле посылка. Кыйммәтле бандероль.*

3. *күч.* Әһәмиятле, бик кирәкле, мөһим. *Дошманның көче, аның нинди участокларга туплануы турында бик кыйммәтле мәгълүматлар җыйдык.* А. Шамов. || Кадерле, кирәкле, газиз. *Җәмгыятькә үзеннән берни дә өстәмичә, үзе көч түкмичә, дегет чиләгедәй, тагылып кына бара икән, ул кеше безнең җәмгыятьнең кыйммәтле кешесе түгел.* Г. Бәширов.

4. *мат.* Кыйммәте (3 мәгъ.) булган, эчтәлеге булган. *Кыйммәтле цифр.*

Кыйммәтле ташлар — матурлыгы, затлылыгы өчен югары бәяләнә, башлыча ювелир әйберләр эшләүгә китә торган минераллар, тау токымнары. *Тау башында төрле-төрле кыйммәтле ташлар: зөбәрҗәтләр, ахаклар һәм башка эре-эре матур ташлар бик күп икән.* А. Алиш. **Кыйммәтле кәгазьләр** *махс.* — капиталистик илләрдә: шул кәгазь ияләренә акчалата табыш алырга хокук бирә торган кәгазьләр (вексельләр һәм акцияләр). *Кыйммәтле кәгазьләр (акцияләр, облигацияләр һ. б.) фонд биржаларында сатып алыналар һәм сатылалар.* Политэкономия.

КЫЙММӘТЛЕ'НЧӘ *рәв.* Бәясенә туры килгән, кыйммәтенә бәрабәр. *Инде хәзинә бер тәңкәлек кәгазь акчага саф үз кыйммәтенчә көмеш бирми, тик 60—70 тиен яки 50 тиен генә бирә, башка кәгазьләргә тагы шулай.* Г. Тукай.

КЫЙММӘТЛЕК *и.* Кыйммәт, кыйбат булу. *Публика ашыга. Билет кыйммәтлегенә карамый.* Г. Гали.

КЫЙММӘТЛЕЛЕК *и. к.* кыйммәтлек.

КЫЙММӘТЛӘНҮ *ф.* Теге яки бу әйбернең хакы, бәясе күтәрелү. *Товарлар кыйммәтләнү.* □ *Бу ел тире-яры, йон-ябага бик кыйммәтләнде.* Ш. Мөхәммәдев.

КЫЙММӘТСЕЗ *с.* **1.** Бәясез, бәясе булмаган. *Чынлап та, һичкем үзенең товарын һичбер бәһасыз, кыйммәтсез, һавадагы торнага яки урамда очып йөргән конфет кәгазенә алмаштырасы килмәс.* Г. Тукай.

2. *хәб. функ. күч. сөйл.* Кадерсез, әһәмиятсез; кадере, әһәмияте булмаган. — *Хәмдиягә асыл егетләр - - - булса, - - - шул җитә. Бүтәннәр аның каршында кыйммәтсез.* М. Фәйзи.

3. *мат.* Кыйммәте (3 мәгъ.) булмаган, кыйммәте юк. *Кыйммәтсез цифр.*

КЫЙММӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* **1.** Бәясе төшү, хакы төшү, арзанаю. *Әйберләр кыйммәтсезләнү.*

2. *күч. сөйл.* Әһәмияте югалу, кыйммәте, кадере бетү.

КЫЙММӘТСЕНҮ *ф.* Кыйммәтрәк дип табу, кыйммәтрәк дип санау. [*Бай белән аның хатыны*], *тагын кыйммәтсенеп, арырак киткәннәр.* Әкият.

КЫЙММӘТЧЕЛ *с.* кыйбатчыл.

КЫЙММӘТЧЕЛЕК *и.* Товарларга һәм азык-төлеккә бәяләрнең бик югары булуы, бәяләрнең күтәренке булуы. [*Беренче бөтендөнья сугышы вакытында*] *бертуктаусыз үсә барган кыйммәтчелек нәтиҗәсендә эшчеләрнең тормыш дәрәҗәсе бик түбәнәйде.* Яңа тарих.

КЫЙМЫЛДАТУ *ф.* Беркадәр хәрәкәтләндерү, беркадәр селкетү, аз гына хәрәкәт иттерү, сизелер-сизелмәс хәрәкәтләндерү (күбрәк әгъзалар турында әйтелә). *Карлыгач-сылу моны күрүгә, алгарак ятып, аяклары кыймылдатты, тезгенне тартты.* Г. Ибраһимов. *Карчык ни әйтергә белми, иреннәрен кыймылдата, ахырда тизрәк чыгып киту ягын карый.* Ә. Фәйзи.

КЫЙМЫЛДАУ *ф.* **1.** Беркадәр хәрәкәтләнү, хәрәкәт ясау, сизелер-сизелмәс хәрәкәтләнү. [*Яшь күзәтче:*] *Әнә курганнан сулдарак бер карамчык кыймылдый-мы?* А. Шамов. || Гәүдәнең теге яки бу әгъзасы хәрәкәткә килү, хәрәкәтләнү. *Аның тавышы чыкмый, куллары кыймылдамый, аягы селкенми.* Г. Бәширов.

2. *күч. сөйл.* Хәрәкәт итү, эшчәнлек күрсәтү, эшләү. [*Сафия:*] *Безнең завком һәм цех ячейкалары бик әкрен кыймылдыйлар.* Ш. Камал.

3. *күч.* Барлыкка килү, үзен сиздерү, чагылып китү (уй-фикер, хисләр һ. б. турында). *Башта Мостафинның күңелендә хурлану һәм ояльу кебек нәрсә кыймылдап куйды, ләкин ул бу тойгыны тизрәк басарга тырышты.* Ә. Еники.

4. *боер. ф.* **кыймылда(гыз)**. *сөйл.* „Тизрәк эшлә(гез), ашыгыгыз“ дигән мәгънәне белдерә. [*Гөлсем:*]

Кыймылдагыз, ут уйнатыгыз, кулыгыз кулга йокмасын. Г. Бәширов.

КЫЙМЫЛ-КЫЙМЫЛ *образлы ияр. диал.* Кешенең хәрәкәткә килүен, хәрәкәтен, яисә берәр нәрсәнең җинелчә селкенүен белдерә. [Михеич] утырган җирендә кыймыл-кыймыл килеп алды. И. Гази.

ҚЫЙНАЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* кыйнау. *Кармак урлауда гаепләнеп кыйналган малай, елап, әрнеп, минем каршыма килеп чыкты.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Нәрсәдән дә булса газаплану, газап чигү, интегү. — *Д без гомер буе ташлыкта, кызыл балчыкта кыйналдык.* И. Гази.

◇ **Кыйналып ташлангандай, кыйналып ташлаган кебек** — 1) тән авыртып, изелеп; арып; 2) *күч.* газапланып, газап чигеп. *Рәүфә, кыйналып ташлаган кебек, әкрен генә урыннан торды, авыр-авыр атлап, башын түбән иеп ишеккә таба китте.* А. Шамов.

КЫЙНАУ *ф.* **1.** Тәнне авырттырырлык итеп кул яки башка берәр нәрсә белән күп мәртәбә сугу, суга-суга тәнне авырттыру яки имгәтү. *Тюков дигән разведчикны немецлар, баганага бәйлап, резина таяклар белән кыйныйлар.* Ә. Айдар. || Нәрсә белән булса да хайваннарга һ. б. ш. ору, сугу. *Еллар безнең белән үтәрләр, Яшьләр тимер булып үсәрләр, Ата казлар кыйнап үскән яшьләр Буржуйларны тотып кисәрләр.* Һ. Такташ.

2. *сөйл.* Шакылдату; бәрү. *Ул да түгел, капканы гөрс-гөрс кыйнарга тотындылар.* И. Гази. *Көн буе күлне мәгънәсезгә [кармак белән] кыйнап йөрдем.* Ә. Исхак. || Берәр әйбернең икенче әйбергә бәрелүе, орынуы турында. *Рәшәткәле тәрәзә каршындагы агач ботаклары җил белән селкенеп ара-тирә пыялаларны кыйныйлар.* К. Нәҗми.

3. Сугышта җиңү, өстен чыгу; (дошманны) тар-мар итү. [*Гәрәй:*] *Аклар белән бергә кара-каршы килеп сугышканда, безнекеләр тегеләрне, әлбәттә, кыйныйлар.* Ш. Усманов. [*Якуб Шәрифҗанга:*] *Немецлар бик каты кыйнамадылармы соң үзегезне? — Төрле чак булды инде, Якуб абзый, кыйнаткан чак та, кыйнаган чак та.* И. Гази.

4. *күч.* Өйрәтү, акылга утырту. [*Мирзахан:*] *Тупас син, әнкәй! Хәзер бит кешеләрне яткырып тәл чыбыгы белән кыйный торган чак түгел, кыйналган кешенең үзе сизмәслек итеп акыл камчысы белән кыйный торган заман.* Т. Гыйззәт. || Кыерсыту, рәнҗетү; газаплау. *Шаярыр идек — әле генә язмыш ханым кыйнаган; елар идек — әле күздән яшебез дә кипмәгән.* Г. Тукай. [*Галиябану:*] *Исмәгыйльгә бирәбез дип җаныкмны кыйнарлар, дип котым чыгып торадыр иде.* М. Фәйзи. || *күч. сөйл.* Тәнкыйтьләү. *Тәнкыйтьчеләр дигән сукбайлар бар, Көн аралаш тотып кыйныйлар.* Һ. Такташ.

◇ **Кыйнап ташлаган кебек** — *к.* кыйналып ташлангандай.

ҚЫЙНАШУ *ф.* **1.** Бер-береңне кыйнау, сугышу. *Күмәкләп кыйнашу.*

2. *сөйл.* Кемне дә булса кыйнау. [*Хәлим Мәхмүткә:*] *Нишләп кыйнашасың... Көчең бик күпмени?* Ш. Камал. || Сугышырга, кыйнашырга һәвәс булу, сугышу гадәте булу. *Шакир - - - үзе усал, кыйнаша.* М. Җәлил.

КЫЙНАШЧЫ *и. диал.* Кыйнашырга яратучы кеше, кыйнашырга һәвәс кеше. *Мин совет йорты янына килеп җиткәндә, авылның мәшһүр кыйнашчысы Исмай агай, кемнеңдер ата-бабасына хәтем укый, дөнья җимереп тавыш күтәреп ятадыр иде.* Һ. Такташ.

КЫЙПЫК *и. диал.* **1.** Китек, кыйпылчык. *Чүлмәк кыйпыклары.* □ *Пулемет утлары, снаряд шартлаулары, гөрелдәп очкан кыйпыклар арасында алтыҗиде сәгать булу әйтергә генә ансат ул.* Х. Мөҗәй.

2. Тукыма яки башка әйберне кискәннән соң калган кисәк, корама. *Ситсы кыйпыклары.*

КЫЙПЫЛУ *ф. сөйл.* **1.** Кыек ярылу, кыелып төшү. *Бер агачны ярганда бер якка китсә, „кыйпылды“ диләр.* К. Насыйри.

2. Кителү, кителеп төшү (китек, кыйпылчыклар турында).

КЫЙПЫЛЧЫК *и.* **1.** Каты әйбердән кителеп, ватылып төшкән кисәк. *Көзге кыйпылчыгы. Чынаяк кыйпылчыгы.* || *күч. сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса хәтерләткән кеше яки нәрсә (к. кисәк). — *Йә, егет кыйпылчыгы, әйт тизрәк.* Г. Бәширов.

2. Бомба яки снаряд шартлаганда барлыкка килгән кисәк, кителәп очкан кисәк, ярчык. *Вагон янында төшеп ярылган бомба кыйпылчыгыннан ике солдат яраланган.* Ә. Айдар. *Икенче көнне иртән снаряд төшеп Якубны яралады: корыч кыйпылчыгы, күн итек кунычын ертып, сум итне умырып алган иде.* И. Гази.

КЫЙРАЛУ *ф. сөйл.* Ватылу, кырылу, җимерелү, юкка чыгу. [*Җиһан:*] *Давылда кыйралган нәрсәләрне барладым. Ике тавыкның аягы сынган, өч чеби үлгән, ике казның канаты каерылган, тәрәзәләр ватылган, чиләкләр яньчелгән.* М. Фәйзи. [*Командир:*] *Бу кыйралган кара урманнар сандугач булып сайрар өчен ул кадәр яраклы җир түгел.* М. Шабай.

КЫЙРАЛЫШ *ф. иск. к.* кырылыш. *Илнең азында йөз еллар буенча сугыш, кыйралыш кебек комачаулардан тыныч булуы кирәк.* Г. Алпаров.

КЫЙРАТ *и. иск., кит. к.* карат.

КЫЙРАТУ *ф. сөйл.* **1.** Вату, җимерү. *„Эх, шул өермә булып, бөтереләп үтсәң иде бер!“ — дип уйлана Габдулла. Нәрсәнедер өерәсе, кыйратасы, тамырыннан куптарып ташлыйсы килә.* Ә. Фәйзи.

2. Тар-мар итү, юкка чыгару, кыйнау. [*Таһир:*] *Сөйлә, сугышларда йөрдеңме? - - - Кыйраттыгыз ничек дошманны?* Ф. Бурнаш. [*Хәмит:*] *Фашистларны кыйратып кайттым да менә ял итеп утырам әле.* Р. Ишморат.

3. *күч.* Берәр эш башкару, ни булса да эшләү. *Күпмени соң әле эш кыйраттым, Күпмени соң әле яшәдем?!* М. Җәлил. — *Минем җирне алдырып, нәрсә кыйраттың син?!* А. Шамов.

КЫЙРАӘТ *и. иск.* Уку, кычкырып уку; яттан уку. *Хәсән бу китаплар арасыннан — яңа рус әдәбияты, рус нәхүе, латинча сарыф, французча кыйраәт китапларын алды.* Ф. Әмирхан.

КЫЙРАӘТХАНӘ *и. иск.* Китапханә, уку залы. [*Себер бае:*] *Безнең сәүдә кыла торган җиребездә дә яшьләр - - - кыйраәтханә файдасына дип театр уйнаганнар иде.* Г. Камал. *Оркида ачылган кыйраәтханәгә күбрәк приказчиклар һәм шәкертләр йөриләр икән.* „Урал“ газетасы.

КЫЙСАС *и. иск.* Кемгә дә булса карата үч, кемнән дә булса алына торган үч. [*Таһир*], *бөтен гаскәрләргә башлык булып, Дошманнардан кыйсас алырга Сугыш мәйданына китәр иде.* Ф. Бурнаш. || *этн.* Канга каршы кан белән җәза бирү. *Кыйсас таләп кыйла [яраланган] Бүре теге Үгездән.* М. Гафури.

КЫЙСЕМ *и. иск.* Нәрсәнең дә булса бер өлеше, кисәге; бүлем. *Җырның калган кыйсемен җырлатмадылар да, киттеләр.* Г. Тукай.

КЫЙСМӘН *рәв. иск. кит.* Өлешчә, кисәкчә. *Шушы сурәтләрдән без бүлмә эчендә кем, нинди караш-*

тагы һәм кыйсмән нинди социаль катлаудагы кеше торганын сизә алабыз. Г. Нигъмәти.

КЫЙСМӘТ *и. иск.* 1. Кисәк, өлеш.

2. Язмыш. *Ләкин ни көтәсең — бервакыт җәй башы иде — ир уртасы гына гаилә башы ата ана белән кызны шул алдау вә ялган белән тулы дөньяда бер дә билгесез бер кыйсмәтнең ихтыярына ташлады да китте.* Ш. Камал.

3. Бәхет; үз өлеше. *Һәр кеше үз кыйсмәтен кыркып ятыр.* Ш. Бабич.

КЫЙССА *и. иск.* 1. Нинди дә булса вакыйга яки кеше турында кечкенә хикәя; хикәят. — *Сез дан чыгарырга теләгән башкорт агайның кыйссасын ишеткәнегез бардыр.* Г. Ибраһимов. [*Сафа*] *әллә нинди кыйссалар сөйләп җибәрә, исең дә китәр.* М. Гали.

2. Художество әсәре, хикәя. *Соңра мин дә, тиз генә көтепханәмә барып, Крыловның „Күке илә Әтәч" кыйссасын янә бер кат укып чыктым да тирән бер фикергә талдым.* Г. Тукай. *Толстой шикелле бөтен галәмнең зур мөхәррирләреннән хисап ителгән затларның шул кыска-кыска кыйссалар язуга гомер сарыф иткәнлеген күз алдыбызга килтерү җитәдер.* Ф. Әмирхан.

3. *дини.* Дингә ышанучылар тарафыннан изге дип саналган кешеләрнең, пәйгамбәрләрнең тормышы турында фантастик хикәя, риваять, легенда. *Нух пәйгамбәр кыйссасы.* □ *Укыталар иде ул вакытта Төрле пәйгамбәрләр кыйссасын һәм аларның төрле „могҗизасын".* М. Гафури.

КЫЙТГА *и. иск.* 1. Нәрсәнең дә булса бер өлеше, кисәге; бүлем.

2. Җир шарының бер кисәге, континент; материкның бер кисәге. [*Батыргали агайның ышануынча*], *Һиндстан кыйтгасы Боз диңгезе буенда, Бәләбәй шәһәре Амур суы янында - - - имеш.* Ш. Мөхәммәдев. *Дуслык кулларын суздык Вьетнамга кыйтгалар аша.* Г. Хуҗиев.

3. *әд.* Шигырь жанры; кыска шигырь, парча. *Бу китап өчен мин үземчә яхшы вә матур дип белгән кыйтга вә шигырьләрне генә сайларга тырыштым.* Г. Тукай.

КЫЙТЫК *с. диал. к.* китек. [*Юлдашевка*] *ачыктаначык сөйләшергә, күңелдәге кыйтык урыннарны ачыкларга, алгы көндә ничегрәк эшләү турында киңәшергә кирәк иде.* Г. Ахунов. *и. нәгъ. Комбайн керә алмаган кыйтыкларны урып яталар.* Н. Фәттах.

КЫЙХЫТЛЫК *и. иск. кит.* Кытлык. *Бервакыт боларның хуҗалары кунаккамы, каядыр китеп озак торгач, мәче баласы һәр көн барып ризыклана торган ашъяулыктан аерылып, моны ачлык, кыйхытлык йөдәтә башлады.* Г. Тукай.

КЫЙШАЙТУ *ф.* 1. Авыш хәлгә китерү, кыегайту, кыек хәлгә китерү. — *Тагын чак кына сулга атладым, агачларымны шул якка табарак кыйшайттым.* Г. Ибраһимов. [*Зөһрә*], *җиләкле савытын кыйшайтып күтәргән килеш, чыга башлый.* А. Әхмәт. || Бер якка салу, кыегайту (башны, иңбашларны). *Карт, кулы белән себерке сабына тотынып, башын кыйшайта төшебрәк кеткелдәп көлә.* Г. Әпсәләмов. *Сәйфи, авызын бөрештереп, башын кыйшайтып куйды.* Г. Бәширов.

2. Кия-кия бер якка чалшайту, кыегайту (аяк киеме турында). *Үкчәләрне кыйшайту.*

3. Чырайны (авызны, иренне) бозып күрсәтү, аларга табигый булмаган рәвеш бирү; чырай бозу. *Чиновник, үткән көннәренең мәгънәсез һәм үкенечле бер вакыйгасы исенә төшкәндәге кебек итеп, авызын кыйшайтып елмайды.* Г. Гобәй.

4. *сөйл.* Кулны, аякны каймыктыру, сөякне буыннар тоташкан урыннан чыгару. [*Гыймади:*] *Анысы йөгерүен йөгерербез, тик менә беләк авырта, әле бер көн уйнаганда, кулны кыйшайткан идем, көрәшеп булса ярар иде.* М. Гали.

КЫЙШАННАК *и. диал.* Кыланчык, кыланчыкланырга яратучы кеше. || *с. мәгъ.* Кыланчык, кыланчыкланырга яратучы.

КЫЙШАННАУ *ф. диал.* Кемгә дә булса ошарга тырышу, кыланчыклану.

КЫЙШАЮ *ф.* 1. Авыш хәлгә килү, кыегаю, кыек хәлгә килү, кыеклану, авышлану. *Авылның читендә кечкенә генә бер якка кыйшайган өй тора.* Ә. Айдар.

2. Кия-кия бер якка чалшаю, кыегаю (аяк киеме турында). *Менә үкчәсе ашалып, кыйшаеп беткән тупас ботинкалы берәү үтеп китә.* А. Шамов.

3. Табигый булмаган рәвешкә килү (чырай, авыз, ирен һ. б. турында). *Мохтарның ирене кыйшайды, чырае сасыган селедка капкан кешенеке төсле булды.* Ш. Камал.

КЫЙШЫК *с. сөйл.* 1. Авыш хәлгә килгән, авышланган, кыегайган. *Безне - - - кәгазь - - - өстенә тезелгән кыйшык нокталар - - - каршы алдылар.* К. Нәҗми.

2. Кия-кия чалшайган, кыегайган (аяк киеме турында). *Кыйшык ботинка.*

3. Табигый булмаган рәвешкә килгән; кыек (авыз, күз һ. б. турында). — [*Кияүнең*] *буе тәбәнәк, йөзе яман шадра, борыны томшык, күзе кыйшык.* Г. Ибраһимов.

КЫЙШЫКЛЫК *и.* Авыш хәлгә килгән булу, авышлык, кыегайганлык. || Кыегаю, авышлану дәрәҗәсе.

КЫЙШЫК-МЫЙШЫК *с. сөйл.* 1. Кыегаеп беткән, авышланган. *Стеналары каралып, сылаган балчыклары коелып, бүрәнәләре күренгәләп торган иске кыйшык-мыйшык өй.* М. Фәйзи.

2. Кыек-мыек. *Аннары, эш өстәлендә өем-өем дәфтәр көтә иде, килеп утырды да кызыл карандашын кыйшык-мыйшык юллар өстендә йөртә башлады.* Г. Гобәй.

КЫЛ I *и.* 1. Ат, сыер койрыгында, ялда, кәҗә, дуңгыз һ. б. тиресендә була торган каты чәч сыман үсенте (көнкүрештә төрле кирәк-яраклар өчен файдаланыла — буяу, кырыну пумаласы һ. б. ясау өчен, кулланыла). *Дуңгыздан бер кыл.* Мәкаль. *Туплауга төшүгә әти белән теге югарыгы оч көтүчесе Камали карт безнең сыер койрыгыннан йолкып биргән кылларыбыз белән чыбыркы төзәтәләр.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Кылдан ясалган, кылдан гыйбарәт. *Кыл матрац.* □ *Бер читкәрәк ертылып беткән иске кыл иләк тәгәрәгән.* А. Гыйләҗев. || Кайбер кешеләрнең битендә, миң өстендә үсә торган каты төк. *Марфаның уң як ияк очындагы миңнең өстенә үскән өч кылның икәвесе өзарган иде.* Ш. Камал. || Каты сакал-мыекның төге. [*Галиулла*] *малайны кочаклап алып, мыек кыллары белән аның битен, муенын кытыклады.* И. Гази.

2. Музыка инструментларында тарттырып беркетелгән һәм тибрәткәндә музыкаль тавыш бирә торган металлдан яки сеңерләрдән ясалган сыгылмалы җеп. *Думбра уйнаучы егетнең кулындагы думбраның кыллары телләнделәр.* М. Гафури. *Ал, гитараңны, сеңел, Ал да кылларын чиерт.* Ә. Исхак. || *күч.* Хис, эчке тойгы; эчке дөнья. *Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын, Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен, Кирәк түгел, мәгънәсе юк көлке, уен.* Г. Тукай. *Нәфисәнең дәртле җыры, яшь мәхәббәтнең иркә һәм тирән төйгыларыдай, күңелләрнең иң нечкә кылларын чиер-*

тә-чиертә, зал эчендә тибрәнә башлады. Г. Бәширов.

3. *физ.* Электр лампаларында кулланыла торган нечкә генә металл чыбык. *Лампа кылы. Электр лампасының кылы янган.*

4. *с. мәгъ. күч. сөйл.* Бик нечкә, бик нәзек (гадәттә, муен турында әйтелә). *Астан кыл муенлы, капкорсаклы бер малай ялынып [менәргә] сорады.* И. Гази.

Кыл елан *зоол.* — к. жеп елан. **Кыл үлән** *бот.* — *к.* чыпчык кузгалагы.

◇ **Кыл (башы) да кыймылдатмау (кыбырдатмау)** — бер нәрсә дә эшләмәү. *[Әнкәй] минем белән киңәшсез кыл да кыймылдатмый.* Г. Ибраһимов. *— Әболар үзләре кыл да кыбырдатмый торып, эшчеләрнең бер көнлек бәйрәмнәренә дә ирек бирмәс өчен каршы баралар.* М. Гафури. **Кылдан нечкә** — артык назлы, артык нәзакәтле. *[Шәрипов] Әгафу итәсез, туташ, мин сезнең бу кадәр кылдан нечкә булуыгызны уйламаган идем.* Ф. Бурнаш. **Кыл да үткәрә алмау** — бер сүз дә каршы әйтә алмау; берничек тә тәэсир итә алмау. *[Хисапчы:] Законны, малай, синең белән миңа караганда яхшырак белә ул. Кыл да үткәрә алмыйсың.* Р. Төхфәтуллин. **Кыл кадәр (дә), кыл чаклы (да)** — аз гына да. *[Жәләл:] Мин гомеремдә кешедән бер кыл чаклы нәрсә алганым, ярдәм күргәнем юк.* Г. Ибраһимов. *Һәм дә җәнҗалдан - - - кыл кадәр ис кермәсен.* Г. Тукай. *[Морат:] Зинһар, минем өчен кыл кадәр дә эшеңнән буленмә.* Н. Исәнбәт. **Кыл кыймылдамый** — бернинди хәрәкәтсез; һич кузгалмыйча. *Илсөяр борылып караганда, пароход инде, су уртасындагы зур утрау шикелле, кыл кыймылдамый утыра иде.* Г. Гобәй. **Кыл (тибрәтерлек) кыймылдатырлык та** — аз гына да, бөтенләй. *[Фәритнең] кыл кыймылдатырлык та хәле юк иде.* А. Шамов. **Кыл кыймылдату (тибрәтү)** — берәр кечкенә генә эш эшләү. *Мин арыган идем, кыл тибрәтерлек көчем калмаган иде.* А. Шамов. *[Солдат:] Күрәсең бит, моңарчы кыл да кыймылдатырга ход булмады.* М. Гали. **Кыл сыярлык та** — бернинди, һичнинди. — *[Тәнкыйтьләү] өчен кыл сыярлык та урын калдырмадың.* А. Шамов. **Кыл чабата кидерү (киендерү)** — бик нык алдау. *[Миңсылу] Юкса безнең абый бик хитрый кеше бит. Шуның өстенә, комсызлыгы да бар. Безгә кыл чабаталары киендермәсен.* Ш. Камал. **Кыл өстендә калу** — 1) көчкә-көчкә исән калу, бетә язу; юкка чыга язу, юк була язу. *Менә әле кышның бер ае үткән юк, ике адәмне шул бураннар шәһит җибәрде. Ничәләренең җаннары кыл өстендә калып, бик зур бәхет илә генә котылдылар.* Г. Ибраһимов; 2) *к.* кыл өстендә тору. *Тагын берничә минуттан ротаның хәле кыл өстендә калачак.* Г. Бәширов. **Кыл өстендә тору** — һәлакәт, бетү алдында тору; куркыныч, хәтәр хәлдә булу. *Әгәр Дәүләтшин шул вакыт Разияның үлем түшәгендә ятуын, аның гомере кыл өстендә генә торуын белгән булса, аңа яшәү тагын да кыенрак булган булыр иде.* И. Гази. **Кылны кырыкка яру (бүлү)** — 1) бик булдыклы булу, уңган, оста булу. *Килделәр ул шәһәргә белгән ирләр, Бер кылны кырык итеп бүлгән ирләр.* М. Гафури. *[Айдар] Кыз түгел — очкын, - - - үсеп җитсә, кылны кырыкка яра торган кыз булыр.* Д. Аппакова; 2) вакчыл кеше булу; вакчыллану. **Кылын басу** — кешенең билгеле бер ягын (үзенчәлеген) белеп эш йөртү, эш алып бару; ул үзенчәлектән файдалану. *[Анасы] мондый вакытларда аның кайсы кылын басарга кирәклеген ачык белә.* Г. Ибраһимов. **Кылын тартып (чиертеп) карау** — кемнең дә булса фикерен-уен белү өчен аны сынап карау, киная белән сорашып, аның уен-фикерен белергә тырышу. *Басудан бергә кайткан чакларда яисә кичке уеннарда [Нәфисәнең] кылларын җыр белән дә чиерткәләп карадылар.* Г. Бәширов. **Кылын тибрәтү** — *к.* кылын тартып карау. *— Сез ничек тә булса, бер җаен туры китереп, аның кылын тибрәтегез, шуннан соң ул, үзе сизмичә үк, фәлән карт заманында авылда фәлән хәл, вакыйга булган елда дип сөйләргә керешер.* Г. Ибраһимов.

КЫЛ II *кис. сөйл.* Нәкъ, иң. *[Шәмсетдин], ак муенлы тимер таягын болгый-болгый, уң ягына бераз аксый төшеп, урамның кыл уртасыннан атлый иде.* Г. Бәширов.

КЫЛАВЫН: кылавын кебек калу *диал.* — бик юкару, бик юкага әйләнү (материя кебек әйберләр турында).

КЫЛАЙТУ *ф.* (Күзне) кылыйлатып карау, (күзнең) кырые белән карау. *Хәлим әле тишектән күренеп торган винтовка түтәсенә карап ала, әле чаттагы кешеләргә күзләрен кылайта.* И. Гази.

КЫЛАНДЫРУ *ф.* **1.** Нәрсә дә булса эшләгәндә мәзәк яки кирәксез, урынсыз кыланышлар ясау. *Газинур кесәсеннән һәйбәт папирос кабы чыгарды һәм аны „кош күрсәтәм, карагыз, очмасын!“ дигәндәй кыландырып, Гарәфи абзыйга сузды.* Г. Әпсәләмов. *Әйләнчек эчендә берәү, бик кыландырып, гармонь уйный, икенчесе зур мичкә кебек нәрсәне „дөң-дөң“ суга.* Ә. Фәйзи.

2. Төрлечә эшләп карау; маташтыру. *[Хәйдәр аякларны] бер тырпайта, бер йомарлый, буыннары кызарганчы, хәле беткәнче, аерым-аерым бөгә, тагын әллә ниләр кыландыра.* Г. Бәширов. || Нәрсә дә булса китереп чыгару, нәрсә дә булса эшләү. — *[Сәләхи] булса, тагын да хикмәтләр кыландырыр иде.* Ш. Камал.

КЫЛАНМЫШ *и. иск. һәм сөйл. к.* кыланыш 1.

КЫЛАНУ *ф.* **1.** Табигый булмаган кыланышлар (хәрәкәтләр) ясау. *Гөлләр каршында [Газинур] аеруча озак һәм кыланып биеде.* Г. Әпсәләмов. || Гомумән, үз-үзенне табигый тотмау; кыланчыклану; назлану. *[Мөгълифә:] Әйдә утыр инде, нәрсә кыланган буласың тагын, бүре түгел ул, сине ашамас.* Г. Камал.

2. Үз-үзен тотуда берәр сыйфатны калку итеп күрсәтергә тырышу. *[Ул мәселман] бигрәк җете кызыл мәэмин булып кылана.* Г. Тукай. || Үз-үзенне тотуда кемгә дә булса охшау, охшарга тырышу. *[Мөршидә]: Менә инде тагын балалар кебек кылана башлады.* Р. Ишморат. *Аларга Габдулланың яучы Биби әби булып укуы һәм кылануы аеруча мәзәк тоелды.* Ә. Фәйзи.

3. Эш итү, эшләү. — *Юк, саксыз кыланырга ярамый.* Ә. Еники. *[Эти:] Их, балам, көненчкә генә булмаса ярар иде синең бу кылануларың, — диде дә бөтенләй мин әйткәнчә эшләде.* Г. Ибраһимов.

4. Нинди дә булса бер эш эшләгән булып күренү, күренергә тырышу. *Безгә карап Рафаэль дә җырлаган булып кылана.* Г. Кутуй. *[Аю] үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган.* А. Алиш.

◇ **Кылануы кырга сыймый** — артык кылану, чамадан тыш кыланчыклану турында. *[Бану:] Уйный белгән кеше кебек пианиногa җәелеп утырган. Кылануы кырга сыймый.* Р. Ишморат.

КЫЛАНЧЫК *с.* Кыланышы табигый һәм гади булмаган, ясалма кыланышлы, чытлык. *Маһруй — сипкелле йөзле, кыланчык кына, Рокыя белән бер класста укый торган бер гимназистка.* Ф. Әмирхан. *Хатын-кызлар, гомумән, Мәдинәне яратмыйлар: „Шадра шайтан, ирдәүкә, кыланчык, ир-ат күңелен аздырып кайнаша...“, — дип, аның гайбәтен сата иделәр,* Щ. Камал.

КЫЛАНЧЫКЛАНУ *ф.* Үз-үзен тотышы, ясалма кыланышлары белән берәрсенә ошарга, аны үзенә каратырга тырышу, чытлыклану. *Кызның кыланчыклануы.*

КЫЛАНЧЫКЛЫК *и.* Кыланчык булу. *Тәрәзәдә, 11—12 яшьләрендә генә булуына карамастан, кыланчыклык әлифбасын тәмам үзләштереп өлгергән, яулыгын арттан бәйләгән, бит алмаларына күп итеп иннек, кершән сөрткән бер кыз бала күренде.* Г. Гобәй.

КЫЛАНЫШ *и.* **1.** Кешенең үз-үзен тотуы, аның тәртибе. — *Мин аның кыланышларыннан баштарак бик ныкшомланган идем.* М. Әмир. *Акбирдиннең бөтен кыланышы ясалма.* М. Җәлил. || Кешенең үз-үзен тотуының тышкы формасы; манера, гадәт. [*Закир:*] *Мин бу көнгә кадәр аның ялганлап, алдалап сөйләгән сүзләренә, үзен гыйффәтле итеп күрсәткән кыланышларына алданып йөргән икәнмен.* Г. Камал.

2. Берәр эшләгән, башкарылган эш-хәрәкәт. [*Сәхәү*] *ике ағасын куып чыгарган да төп йортта калган. Бу кыланышлары өчен аны ике ағасы да, карт анасы да яратмаганнар.* М. Әмир. [*Нургали*] *кызлар алдына барып төрле матур кыланышлар ясый.* М. Фәйзи.

◇ **Кыланышы кырга сыймый** — *к.* кылануы кырга сыймый.

КЫЛАНЫШ-ТОРЫШ *и.* Кешенең үз-үзен тотуы һәм аның тышкы чагылышы. *Гайшәдән соң керәшен бабай кертелде. Башында картуз ... бөтен кыланышы-торышы буенча коеп куйган рус мужигы.* Г. Ибраһимов.

КЫЛАУ *и. диал.* Күзнең мөгез катлавы калынаюдан гыйбарәт авыру; катаракт. *Күзне кылау каплаган.*

КЫЛАЮ *ф. диал.* **1.** Кыегаю, авышу. *Сыңар тәрәзнең бака кашыгы төсле утлы-яшелле өч өлгесе өчесе өч якка кылайган.* Г. Бәширов.

2. Ничек туры килде шулай аву, яту. *Ә таң алдыннан - - - кайсың кайда кылаеп, черем итеп аласың.* Ф. Хөсни.

КЫЛБЫРДАК *и. диал.* Ыгы-зыгы, тәртипсез эш-хәрәкәт. **Кылбырдак килү** — ыгы-зыгы килү. *Йортлар тирәсендә кылбырдак киләләр, тыз-быз йөриләр.* А. Гыйләҗев.

КЫЛГАН *и.* Кыяклылар семьялыгыннан яфракларын озын тар кыяклар тәшкил иткән, йомшак себеркәч чәчәкле дала үләне; *русчасы:* ковыль. *Дала һәм чүл үсемлекләре корылыкка чыдам булалар: андый үсемлекләргә мисал итеп кылган һәм әремне күрсәтергә була.* Ботаника. *Кыякларын җәя кылганнар, Тубылгылар суза яфрагын.* Ә. Ерикәй.

Кылган чүгы — кылганның себеркәчле чәчәге. [*Кызның чәчләре*] *кылган чүгыдай аксыл-сарылар.* М. Хәсәнов.

КЫЛГАНЛЫК *и.* Тоташ кылган үскән урын, тоташтан кылган каплаган җир. *Агыйдел дә буе, ай, кылганлык, бер бөртекләре дә кыл кебек.* Җыр. *Тимербикә апа - - - кылганлык[ны] күрсәтте.* Ә. Баян.

КЫЛДАУ *и. диал.* Чиләк бавы. *Кылдавына бау бәйләнгән чын чиләк тотып, Майсәрә кое янына барып басты.* Н. Фәттах.

КЫЛДЫ-БЫЛДЫ *рәв. сөйл. к.* кылтый-мылтый. — *Син алай, кылды-былды буталып йөрмә, яме?* Т. Гыйззәт.

КЫЛДЫЙ-БЫЛДЫЙ, КЫЛДЫЙ-ПЫЛДЫЙ *рәв. сөйл. к.* кылтый-мылтый. *Нишләрен белми, мәтәкли, җилпенә. Кул-аяклар кылдый-пылдый селкенә!* Ш. Бабич. [*Хәсби апа*] *шулай кылдый-былдый йөри торгач, күмер савытын түгеп җибәрде.* Ак юл.

КЫЛКА *с. диал.* **1.** Тузып теткәләнгән, тузып телгәләнеп беткән. *Без йокыдан торабыз да, тула оекларыбыз булмаганга, аякка ыштыр чолгап чабата киябез; мин өскә әлеге әтинең кылка чикмәнен киям.* М. Гали.

2. *күч.* Ябык, ябыгып беткән; арык (кеше турында).

КЫЛКАЛАНУ *ф. диал.* Тузып теткәләнү, телгәләнеп бетү (кием турында). *Минем өскә киергә булмаганга, иртәнге салкыннарда киеп йөрерсең дип, әни әтинең иске тәвәккәл бүреген һәм аның җиңнәрен, итәк очларын бераз кыскартып, - - - искереп, кылкаланып беткән тула чикмәнен бирде.* М. Гали.

КЫЛКОЙРЫК *и.* **1.** Башка үрдәкләрдән аермалы буларак, койрыгында ике озын каурые булган кыргый үрдәк.

2. *күч. диал.* Алдакчы, үз сүзендә тормаучан (кеше).

КЫЛКЫЛДАУ *ф. сөйл.:* **кылкылдап тору** — нәрсәне дә булса ашарга, эчәргә яки берәр эшкә атлыгып тору.

КЫЛКЫН *и. диал.* Бугазның башланган урыны. *Комагай кылкыныннан яза, кыдырма аягыннан яза.* Әйтем.

КЫЛКЫНУ *ф. сөйл.* Кайнашу, сырпалану. [*Марзия:*] *Һи! Синнән яшьрәкләр әле аның тирәсендә кылкынып йөрерләр, Халикъ абзый.* Ш. Камал. || *күч.* Бик нык түземсезләнү, зур түземсезлек күрсәтү. *Гөрләвек дулкыннар арасында зирәк кош кебек оча-калка килгән көймә, кылкынып ук көтеп торган халык алдына килеп, көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып итеп туктады.* Ш. Камал.

КЫЛЛАУ *ф. сөйл.* **1.** Йонны, мамыкны кылдан арындыру. *Дебет кыллау.*

2. *рәв. мәгъ.* **кыллап.** Кыл кушып, кыл катнаштырып. *Камчыларын кырлап үргән, Тармакларын кыллап үргән.* Ш. Маннур.

КЫЛЛЫ *с.* **1.** Кыл катнашкан, кыл кушып ясалган. *Кыллы чыбыркы.*

2. Кыллары (2 мәгъ.) булган, кыллар ярдәмендә тавыш чыгара торган (музыка кораллары турында). *Биш йөз шәкертле мәдрәсә эчендә бер генә данә дә гармонь яки кыллы музыкалардан берен белүче булмаганга, андый нәрсә булмый, булса кубыз да курай яисә авыз музыкасы.* Г. Ибраһимов. || Шундый музыка коралларыннан торган. *Кыллы квартет.* □ *Кабакларда кыллы оркестрлар мазуркалар белән яңгырый.* Һ. Такташ.

3. *физ.* Нечкә металл чыбыгы булган. *Кыллы гальванометр.*

КЫЛПА: кылпа күз *иск.* — 1) кысылган күз; 2) *күч.* кырын карау; үз итмәү. [*Карчык*] *көтмәгәндер карттан андый кылпа күз, Көтмәгәндер мондый ямьсез, дорфа сүз.* Н. Исәнбәт.

КЫЛПАЙТУ *ф. иск. к.* кылпакландыру.

КЫЛПАКЛАНДЫРУ *ф. иск.* Кысу, кысып карау. *Күзне кылпакландыру.*

КЫЛСЫЗ *с. муз.* Кылы, кыллары булмаган; кылга, кылда уйнауга нигезләнмәгән (музыка кораллары турында).

КЫЛТ *рәв.* Кинәт, капыл. *Начальник, урынныннан кылт сикереп торып, сестраны бүлде.* Г. Гобәй.

◇ **Кылт итеп искә төшү** — нәрсә дә булса кинәт искә төшү; уйламаганда искә килеп төшү. [*Хәлим*] *инде борыла да башлаган иде, кылт итеп атасының әйткән сүзләре исенә төште.* И. Гази. *Шунда минем исемә кылт итеп килеп төште.* А. Шамов.

КЫЛТАЙ *с. диал.* Мактанчык, тәкәббер. *Соңгылары күбесенчә кылтай ир егетләр, мыек та чыкмаган әче телле яшүсмерләр.* Э. Касыймов.

КЫЛТАЙТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* кылтаю.

2. *диал.* Аз гына ачып кую. *Ишекне бераз кылтайтып кую.*

КЫЛТАКЛАНУ *ф. диал. к.* кылтаю.

КЫЛТАМАК *и. сөйл.* Аш үтмәү чире, ашый алмау чире. *Анасы Мәргыя карчыкның авыруын, кылтамак чирен, әченә аш үтмәвен, капкан бер нәрсәсе кире чыга торуын Мәрхәбә тегендә чагында ук ишеткән иде.* Г. Ибраһимов. *Комагай кылтамакка калыр.* Мәкаль. || Аш үтмәү чире белән авырган кеше.

КЫЛТАЮ *ф.* 1. *сөйл.* Үпкәләү, хәтер калу, кәеф китү. *Берәр нәрсәгә кылтаеп, син буржуй дип чыгып китә.* Ә. Таһиров. *Түзмәдем, өйалдына чакырып чыгардым тегене [Госманны]: „Я телеңә салынмыйча гына утырасың, я мин сине тәрәзәдән атам", — дидем. „Мактаганга нигә кылтаясың, кәләшеңне мактыйм ич", — ди.* Ф. Хөсни.

2. *сөйл.* Эреләнү, тәкәбберләнү, борын күтәрү, үзүзен зурга санау. *[Мөгаззәмә], черки күп [авылда], яши алмыйм дип, үзе кылтаеп йөргән.* Г. Мөхәммәтшин. || *диал.* Үсенү, үсенеп китү (балалар турында).

КЫЛТЫЙ-МЫЛТЫЙ, КЫЛТЫЙ-ПЫЛТЫЙ *рәв. сөйл.* Кыек-мыек. || Кыек-мыек басып. *Колга буйлы бер кеше кылтый-мылтый боларның каршысына килә иде.* И. Гази.

КЫЛТЫК *с. диал. к.* кылтым. *[Гайнижамал:] И, кылтыклар, кыланган булдылар тагы!..* И. Гази.

КЫЛТЫМ *с. сөйл.* Үз-үзен зур санаган, борынын күтәргән, эре. *Бу егетнең офтанганына каршы бу кылтым бай, нишләр икән дип, кызык өчен моңар бер йөз тәңкә акча биреп тора.* Әкият.

КЫЛТЫН *с. сөйл. к.* кылтым. *Аның каршысында картаеп сакал җиткергән олы кешеләр түгел, хәзерге заманның кылтын яшьләре басып тора иде.* Г. Ахунов.

КЫЛТЫРАТУ *ф.* Нәрсәне дә булса селкетеп яки нинди дә булса башка юллар белән кылтыр-кылтыр китерү.

КЫЛТЫРАУ *ф.* Кылтыр-кылтыр килү, кылтыр-кылтыр килгән тавыш чыгару. *Бер үлчәүдә: кырау, сорау, мияу, мырау, һәм кылтырау, һәм шылтырау, һәм кыңгырау.* Г. Тукай.

КЫЛТЫР-КЫЛТЫР *аваз.ияр.* Эче куыш предметларның яки артык авыр булмаган башка предметларның берсе икенчесенә җиңелчә бәрелеп торган вакытта яки бәргәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Тәрәзә пыялалары кылтыр-кылтыр килеп тора.* Г. Ахунов.

КЫЛУ *ф. иск.* 1. *кит.* Нәрсә дә булса эшләү, нинди дә булса эш башкару. *Ни кылырсың, Хажи абзый, тотса Мәскәүләр якаң?* Г. Тукай. *Кулы белән кылганын муены белән күтәрер.* Г. Ибраһимов. || Нәрсәне дә булса оештыру, үткәрү; ясау. *Искәндәр бай - - - унҗиде яшендәге кызын биреп, өч мең тәңкә расход тотып, бик зур туй кылып, никах мәҗлесе үткәрде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *ярд. ф. функ.* 1) *к.* итү. *Күп тырыштым һәм күп көчләр сарыф кылдым.* М. Гафури. *Соңгы сынашларга Таһирны Чакырырга карар кылдылар.* Ф. Бурнаш; 2) дини ритуалны белдергән исемнәр белән килгәндә, шул ритуалны башкару мәгънәсен аңлата. *Карчык утырган җирендә кул күтәреп дога кылды.* Г. Ибраһимов. *[Хажи] ике генә тапкыр сәҗдә итәсе урында, тугызмы, унмы тапкыр сәҗдә кылды.* Ш. Камал.

КЫЛЧЫК *и.* 1. Кыяклы игеннәрнең башагында була торган озынча нечкә каты мыекча үсенте. *[Гайшә:] Батыржанны ындыр табагын теле белән ялатырмын — бер кылчык калдырмам.* Ф. Бурнаш.

2. Балык умырткасының кабырга сөякләре. *[Ильяс абзыйның] иягендә генә калдырылган кара сакалында да балык кылчыклары күренә.* Г. Гобәй.

КЫЛЧЫКЛАНУ *ф.* Кыяклы игеннәрнең башагында кылчыклар, озынча мыекчалар барлыкка килү.

КЫЛЧЫКЛЫ *с.* 1. Кылчыклана торган, кылчыклар үсә торган. *Кылчыклы бодай.*

2. Кабырга сөякләре күп булган, кылчыклары күп булган (балык турында). *Кылчыклы балык.*

КЫЛЧЫКСЫЗ *с.* 1. Кылчыкланмый торган, кылчык үсми торган. *Кылчыксыз бодай. Кылчыксыз кындырак.*

2. Кабырга сөякләре булмаган яки бик аз булган; вак сөякләре аз булган. *Кылчыксыз балык.*

КЫЛЫЙ *с.* Күз каралары бер юнәлештә булмаган, төрле юнәлештә булган (күзләр турында). — *Кылый күзле Фәрхиҗиһанга кияү табып биргәнем өчен, әнкәсе мәрхүмә [чапан] бүләк итеп биргән иде.* Ш. Камал. *Кылый күз бабай шундый ук ачыклык белән хөкем алдында әйтте.* Г. Ибраһимов. || *сөйл.* Кылый күзле. *Мин бер кылый егетнең уйнавына тәмам гашыйк булып, әллә нихәтле артыннан ияреп йөрдем.* Ә. Еники. *Авыл Советы рәисе Шәңгәрәй Тимеркәев хатыны Рәгыя белән кылый Гыймади карт Садыйкка кара тап сүзләр яудыра башладылар.* Г. Нигъмәти.

КЫЛЫЙК *и. диал.* Бармак юанлыгындагы кыска гына агач кисәгенең бер ягын очлап, икенче ягына үзенә бер төрле ике каурыйны утыртып, һавага ата торган балалар уенчыгы.

КЫЛЫЙЛАНУ *ф.* Кылыйга әйләнү, кылый булу. *Шунда Фазылҗан абзый Касыймның болай чибәр генә кара күзләре чыннан да борын төбенәрәк бик яман кылыйланып киткәнен күреп алды.* Р. Төхфәтуллин.

КЫЛЫЙЛЫК *и.* Күз караларының төрле юнәлешкә караган булуы (күз авыруы).

КЫЛЫК *и. иск., диал.* 1. Эшләгән, башкарган эш; эшли торган эш. *Кыз кылыгы белән сөйкемле, ул әдәбе белән сөйкемле.* Мәкаль. *[Сабир:] Минем дәгъвам бар: [берәр кешенең] кылган кылыкларыннан бераз сөйләсәләр, шуннан мин аның табигатен үтә күрермен, җанына керермен дип ышанам.* Г. Ибраһимов.

2. *диал.* Холык.

КЫЛЫКЛЫ *с. диал.* Яхшы холыклы. *Һөнәрле булып ул үссен, кылыклы булып кыз үссен.* Мәкаль.

КЫЛЫМ *и. иск. к.* фигыль 3.

КЫЛЫНДЫРУ *ф. диал. к.* кыландыру 1. *Чырайларын әллә нишләтеп, еларга хәзерләнгән шикелле кылындыра.* Ш. Камал.

КЫЛЫНМЫШ *и. иск.* Эшләгән эш. *Агач беленә җимешеннән, адәм кылынмышыннан.* Мәкаль.

КЫЛЫЧ I. *и.* 1. Кешене чабып яки чәнчеп үтерү өчен хезмәт итә торган берничә төрле салкын озын коралның исеме: 1) бер йөзе генә үткен кәкре озын корыч пластинкадан гыйбарәт корал; *русчасы:* сабля. *Кылыч сабы.* □ *Иелгән башны кылыч кисмәс.* Мәкаль. *Бере күкрәгенә берсе кылычларын чәнечкәннәр.* Г. Тукай; 2) ике йөзе дә үткен, озын туры корыч пластинкадан гыйбарәт борынгы корал; *русчасы:* меч. *Нәкъ борынгы тәре сугышындагы христиан фанатигынча, изге бер дини гамәл үтәгән кыяфәттә, киң һәм төз кылычын тантаналы рәвештә туп-туры өскә төзәп, ике каш арасына тоткан, артыбыздан да каравыллар бар.* Н. Исәнбәт; 3) ике ягы да үткен булган аз гына кәкре корыч пластинкадан гыйбарәт корал; *русчасы:* палаш.

2. *күч. иск. хәрби лексикада:* сугышчы кавалерист, кылычлы сугышчы. *Биш йөз кылычтан торган отряд.*

3. *күч.* Нәрсәне дә булса юкка чыгара торган көч, куәт символы. *Революция кылычы контрларны шу-*

лай юкка чыгарды. Г. Ибраһимов. *Совет илендәге көчле тәнкыйть — Җитешсезлекләрнең башын кисеп ташлый торган кылыч ул.* М. Гафури.

Кылыч балык *зоол.*— 1) дингездә яши торган, югары казналыгы кылычсыман очлаеп үскән зур балык; *русчасы:* меч-рыба. *Диңгез төбендә еш кына коточкыч сигезаяклар, дәһшәтле кылыч балыклар белән сугышып, көненә берәр мыскал асыл энҗе тапканнар алар.* Р. Төхфәтуллин; 2) *диал.* карплар семьялыгыннан, төче суларда яши торган балык; *русчасы:* чехонь. **Кылыч борын** — юка сыртлы туры борын. *Какча йөзле, кылыч борынлы студент, карарны укып чыгып, тавышка куйды.* А. Расих. **Кылыч тешле юлбарыс** — мәчесыманнар семьялыгыннан югарыгы казык теше кылычны хәтерләткән казылма ерткыч хайван. *Кылыч тешле юлбарыслар --- кешеләрне сагалап йөргәннәр.* СССР тарихы. **Кылыч уены** — салкын корал (рапира, шпага һ. б.) белән эш итү осталыгына нигезләнгән спорт уены. **Кылыч уты** *иск., диал.* — *к.* кылыч үләп. **Кылыч үләп** *бот.*— сазлыкта үсә торган кылыч сыман кыяклы үләп, сусын; *русчасы:* аир.

◇ **Кылычка кылыч килү** — якыннан торып сугышу, кара-каршы килеп сугышу. [*Бикмүш бабай:*] *Кулны өздергәнсең димме?* [*Өметбаев:*] *Контратака вакытында --- кылычка кылыч килгәндә.* Г. Гобәй. **Кылыч күтәрү** — сугыш ачу, сугыш башлау. *Үндүрт илнең буржуйлары күтәрде безгә кылыч.* Г. Хуҗиев. **Кылычтан кичерү** — кылыч белән чабу, кылыч белән чабып үтерү. [*Мораташ*], *Идел кичеп, ил гизеп, алпавытларны кылычтан кичереп, бик озак сугышып йөргән.* Г. Бәширов.

КЫЛЫЧ II *и.* **1.** Туку станогында: һәр аркылы җепне (аркауны) сугыла торган тукымага китереп беркетеп куярга ярдәм итә торган зур тарак сыман әсбап, деталь. [*Киндер сугу станогының*] *--- аяклары какшап, кылыч, шүреләре коргаксып беткән.* Г. Ахунов. *Агай чыпта суга, ә малай станның „кылычын“ күтәреп тора иде.* А. Расих.

2. *диал.* Җитенне, киндерне талкыганнан соң сүсне йомшарту һәм чистарту өчен кулланыла торган юка гына агач калак.

КЫЛЫЧАЕП: кылычаеп торган — юка сыртлы (борын турында). *Ә кылычаеп торган озын һәм матур борын---егетнең йөзенә горурлык биреп тора.* Ә. Фәйзи.

КЫЛЫЧБАЗЛЫК *и. иск. к.* кылыч уены.

КЫЛЫЧЛЫ *с.* Кылыч таккан, кылыч белән коралланган. *Тирә-ягында --- медальле күкрәкләрен киереп, сары төймәле, кайсылары кылычлы бик мәһабәт тугыз адәм утыра.* Г. Ибраһимов. || *и. мәгъ.* Кылыч белән коралланган, кылыч таккан кеше. *Партизаннар, ак банданы тар-мар итеп, пароходларга төялеп китүгә, Агыйдел буена солдатлар, кылычлылар килеп тулды.* Г. Гобәй. || *и. мәгъ. иск. сөйл.* Полициядә хезмәт итүче; полициядә хезмәт итүче түбән чинлы кеше. *Ике данә кылычлы янга килгән.* Г. Тукай. *Өйгә бер-бер артлы дүрт кылычлы килеп керде.* Ә. Фәйзи.

КЫЛЫЧЧЫ *и. иск.* Кылыч ясаучы, кылыч ясаучы оста.

КЫЛҖАЮ *ф. диал. к.* калҗаю. *Алганда аның стеналарыннан җил өреп, түбәсеннән яңгыр үтеп торса да, Гыйльмениса җиңги, үзенең булганлыгы аркасында, стеналарын кызыл балчык белән сылап, кылҗайган бүрәнәләрен терәтеп, түбәсенә балчык өеп, яхшы гына ныгыткан иде.* М. Гали.

КЫЛҖЫ-МЫЛҖЫ *рәв. диал.* **1.** Кыек-мыек (атлау).

2. *күч.* Бер болай, бер тегеләй; җитди түгел, төпсез (сөйләү, фикер йөртү). [*Ярми карт*] *хәзерге халыкны „кылҗы-мылҗы“сы өчен сүгеп, әүвәлгеләрне сагына.* Г. Ибраһимов.

КЫМ-КЫРЫЧ *с. диал.* **1.** Бик күп, исәпсез-хисапсыз. [*Давытның*] *дус-ише кым-кырыч аның.* А. Гыйләҗев.

2. Эш тыгыз, вакыт тар булу турында. *Кым-кырыч чак.*

◇ **Кым-кырыч килү** — мәш килү, нинди дә булса эш белән мавыгу. [*Кайнеш:*] *Утар-абзарларны төзәтеп, атлар двуры ясыйбыз. --- Кым-кырыч киләбез.* С. Рафиков.

КЫМТУ *ф.* **1.** *сөйл.* Атка атланып барганда аны тизләтү өчен аяклар белән янтыгына төртү. *Закир --- атны аяклары белән бер кымтый, чыбыркы белән кабыргага, очага бер бирә дә дулатып чаптырып китә.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл.* Кысу, ник кысу. *Иреннәрне кымту.*

3. *диал.* Бөкләү, кыстыру, җыю, җыеп кую. *Итәкне кымтып утыру.* □ *Юрганыңның тирә-ягын кымтып ят.* Т. Ченәкәй.

КЫМТЫРЫКЛАУ *ф.* **1.** *сөйл.* Кармау, кармалау; капшау. [*Сәфәргали*] *кесәсендәге --- сабынын кымтырыклый.* Ф. Хөсни.

2. *сөйл.* Өзлексез сорап тору; үтенү, сорап йөдәтү.

3. *диал.* Аз-азлап алып тору; сиздермәстән алу.

КЫМШАНУ ф. **1.** Торган (баскан, утырган) урыныннан кузгалу, аз гына хәрәкәткә килү, хәрәкәтләнү. *Барый, --- тешен кысып, бер урында кымшанмыйча тик торды.* Н. Фәттах.

2. Нәрсә дә булса эшләргә тотыну, нинди дә булса эшне башлау; кузгалу. [*Сәрвәр:*] *Өеңнең стеналары өстеңә җимерелеп төшми торып, кымшана белмәссең ахры син.* Р. Төхфәтуллин. || Нәрсә дә булса эшләргә уйлау; берәр эш эшләргә булу, карар итү. [*Җәлә:*] *Бурычка дигән булып, азрак кылын тартып караган идем, бер дә кымшанмый.* Ш. Камал.

3. Селкенү, какшап, селкенеп тору, урыныннан кузгалу (бушаудан һ. б. сәбәпләрдән). [*Гәрәй:*] *Кайбер кымшаныбрак торган забойлар була ич.* Ш. Камал.

КЫМШАТУ *ф.* Нәрсәне дә булса урыныннан кузгату, хәрәкәткә китерү (күбрәк әгъзалар турында әйтелә). *Аннары дгъләм, салам астына тыккан аякларын кымшатып, офык ягына карап, зарланып алды.* С. Рафиков. *Шунда ук [Җамали] уң кулының иңбашы гәүдәсенә беркетелеп бәйләнгәнлеген белде. Ул аны кымшатмакчы булып карады, ләкин булдыра алмады.* М. Гали.

КЫМШАУ *ф. диал. к.* кымшану.

КЫМЫЗ I *и.* **1.** Бия, дөя яки кәҗә сөтеннән махсусысул белән ачытып ясалган эчемлек (кайбер авыруларны, мәсәлән, үпкә авыруын дәвалау өчен дә кулланыла). *Күпме кымыз бирсә дә, кәҗә бия булмас.* Мәкаль. *Кымызны эчеп, бераз исереп алгач, Сарсымбай Азым әкәне читкә алып сөйләште.* Г. Ибраһимов. [*Табиб*] *миңа карап, кымыз эчәргә кирәклеген вә бик тиз Петербургтан китәргә тиешлеген сөйләде.* Г. Тукай.

2. *сөйл.* Кымыз белән дәвалау урыны. [*Гали Зөләйхага:*] *Хәзер авыруым --- кымызга барып кайтыйм әле,— дип әйттең. Әмма кымызга бармадың.* Г. Коләхметов.

КЫМЫЗ II. *и. диал. к.* кымызлык.

КЫМЫЗЛЫК *и. диал.* **1.** Яфракларында һәм сабагында кузгалакныкы кебек эче кислотасы булган үләнчел үсемлек; *к.* какы; *русчасы:* кислица. *Яз көнендә, кырда йөргәндә, ичмасам, карын ачып китсә, какы, кәҗә сакалы, кымызлык кебек төрле үсемлекләр ашап тамак ялгап җибәреп була иде.* М. Гафури. [*Фатыйма*] *зур кызларга ияреп җуа, кымызлыкларга йөри башлаган.* Ф. Кәрим.

2. Әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан сары чәчәкле, гадәттә, басуда үсә торган үләнчел үсемлек; *к.* ачы какы; *русчасы:* свербига восточная. *Чыршы урманындагы үләнчел үсемлекләрнең күпчелеге (ландыш, кымызлык, бүре җиләге) тамырчалардан үрчиләр.* Ботаника.

КЫМЫЗХАНӘ *и.* Кымыз эчә торган урын, ханә. *Кабанның аргы башындагы дачаларга, ресторанлы „Аркадия" бакчасына, эргәсендәге кымызханәгә баручы-кайтучы, минем ише „сәяхәт" һәм истирахәт итүчеләр өзелеп тормый.* И. Рәмиев.

КЫМЫЗЧЫ *и.* 1. Кымыз ясаучы, кымыз ясаучы оста. | *с. мәгъ. Кымызчы малай.* □ *Бу кымызчы башкортлар янында яшел чирәмгә паласлар, киезләр җәеп, табын-табын кешеләр утыралар — байлар, муллалар кымыз эчәләр.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл.* Кымыз белән дәваланучы. [*Хәйри:*] *Кымызчылар ята торган башкорт авылларына берничә кеше җибәрсеннәр.* Г. Ибраһимов.

КЫМЫЗЧЫЛЫК *и.* Хуҗалык тармагы буларак кымыз хәзерләү эше.

КЫМЫРЫСКА *и. иск. һәм диал. к.* кырмыска.

КЫМЫРҖУ *ф.* Беркадәр кычыту, кычымсырау, кычытып тору; кычытыр-кычытмас тору. *Бу минутта Нургалинең дә күңеле нечкәреп китте, ничектер күзләре дымланып, тамак төбе кымырҗып куйды.* Ә. Еники. *Тел кычыта, бугаз кымырҗый иде.* Ф. Әмирхан.

КЫМЫРҖЫТУ *ф.* Беркадәр кычыттыру, кытыклап тору. *Зур каравай калачның күз алдында торуы авызларыбыздан сулар китерә, тамакларыбызның төбен кымырҗытып тора иде.* М. Гафури.

КЫН I *и.* Кылыч, хәнҗәр кебек кораллар өчен савыт, футляр. *Кылыч кыны.*

КЫН II *и. махс.* Франс ярусының астан икенче катлавы — геологик катлау. *Кын балчыгыннан соң 100 метрлы интервал нибары бер тәүлектә үтелде.* Соц. Тат.

КЫНА I *и. бот.* 1. Бик аз гына кагылганда да җимеше ачылып китә торган үләнчел үсемлек; *русчасы:* недотрога. *Үсеп утырган кына.*

2. *махс.* Чәчне, тырнакларны, тешне буяу өчен кулланыла торган саргылт, саргылт-кызыл яки кара буяу. *Тырнакларына кына ягынмак кеби нәрсәләр боларда бик модадыр.* З. Бәширн. [*Хәдичә:*] *Теш кынам шәп кунганмы?* К. Тинчурин. [*Вәлишин*] *бүген генә кынага манылган җирән сакалыннан бер тотам төкләр йолкыды.* К. Нәҗми.

Кына гөле — өйдә үстерелә торган алсу чәчәкле гөл; *русчасы:* бальзамин. *Кына гөле, үзенең кып-кызыл чәчәкләре белән Хөсәенне чакыргандай, матур булып балкып утыра иде.* А. Расих.

КЫНА II *и. иск.* Хин агачының кабыгыннан алынган ак төстәге порошок, бизгәккә каршы кулланыла торган дару; хинин. [*Җәүдәт:*] *Ник болай калын киендегез, әллә хәмә (бизгәк) хәстәлегенә бирелдегезме? Кына, кына эчәргә кирәк.* Г. Газиз.

КЫНА III *кис. к.* гына. *Менә Фазыл Гөлләргә үзенең хатыны булырга тәкъдим ясаган, ә Гөлләр аңа дус кына булыйк дигән.* Г. Әпсәләмов. *Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел.* Г. Тукай.

КЫНДЫРАК *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан булган үлән, айравык; *русчасы:* костер. *Кысыр кындырак. Кылчыксыз кындырак.* □ [*Себердә*] *кылчыклы кындырак, керпе үләне, клевер кебек үләннәр зур урын алган.* А. Фаткуллин. || Шул ук семьялыктан булган чүп үлән. *Арыш кындырагы.*

КЫНТАР: кынтар кабагы *бот.* — тышкы күренеше белән шешәгә охшаган, ашарга ярамый торган кабак (кабыгы савыт итеп кулланыла); *русчасы:* горлянка.

КЫНТЫРЫКЛАУ *ф. диал. к.* кымтырыклау.

КЫНҖЫРАК *и. иск., этн.* Ат, сыер аягы тиресеннән чабата сыман итеп тегелгән аяк киеме. — *Колакчын белән кынҗырагыңны ки дә, муеныңны коллыкка и.* Шура. || Чабата астына тегеп куелган ат яки сыер аягы тиресе.

КЫП I *аваз ияр.* Нинди дә булса предметны бер җиргә кинәт кенә куйганда барлыкка килгән тавышны белдерә. [*Сәхәп*] *янындагы урындыкны чак кына кутәреп, кып иттереп урынына төшереп куя.* Н. Исәнбәт.

КЫП II *рәв. диал.* Нәкъ. *Кып урталай.*

КЫП-КЫЗУ *с. арт. дәр. к.* кызу II. *Кып-кызу яшь бөртекләре белән Чыланып чуарланды битләре.* М. Гафури.

КЫП-КЫЗЫЛ *с. арт. дәр. к.* кызыл. *Ботакларны сарып алган кып-кызыл алма арасыннан яфрак та күренми.* И. Гази. [*Зөһрә:*] *Менә бу кып-кызыл, эреэрә, иң тәмле җиләкләрне этиемә дип калдырдым.* А. Әхмәт.

КЫПКЫН *и. иск.* Очкын, чаткы.

КЫПКЫНЛАНУ *ф. иск.* Очкынлану, очкынланып яну.

КЫП-КЫСКА *с. арт. дәр. к.* кыска. *Аннары аның белән бергә тәбәнәк буйлы, кып-кыска аяклы, шар кебек түгәрәк бер хатын - - - килде.* А. Шамов.

КЫПЛАМА *и. иск.* Кыйбланамә. (*к.* компас).

КЫПСУЫР *и. диал.* Кадакларны суырып чыгару өчен хезмәт итә торган кыскычлы инструмент, келәшчә.

КЫПТЫР, КЫПТЫР-КЫПТЫР *аваз иярт.* Берәр нәрсәгә (мәсәлән, каткан тирегә) орынудан килеп чыккан тавышны, шактый каты кыштырдауны белдерә.

Кыптыр-кыптыр килү — шактый каты кыштырдау, кыштырдау авазлары чыгару. **Кыптыр тун** — тупас иләнгән тиредән тегелгән тун (хәрәкәтләнгәндә кыптырдап торуыннан чыгып бирелгән исем). *Кырык кат чабадан кыптыр тун артык.* Мәкаль.

КЫПТЫРДАУ *ф. сөйл.* Кыптыр-кыптыр килү.

КЫПЧАК *и.* Урта гасырдагы төрки телле халыкның атамасы һәм шуның бер кешесе (Азиядә—кыпчаклар, Русьта — половецлар, Европада—куманнар дип йөртелгәннәр). *Нәкъ шул вакытта көнчыгыштан күчмә халыклар — кыпчаклар Киевка куркыныч салалар.* СССР тарихы. || *с. мәгъ.* Кыпчак халкына караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Алтын Урда хакимлек иткән гасырларда Идел һәм Урал буйларында - - - кыпчак теле бик киң тарала.* Каз. утл.

КЫПЫЛ-КЫПЫЛ *обр. ияр.* Күз яше тамуны белдерә. *Конрад инде баядан бирле Наҗиянең кыпылкыпыл тамган күз яшьләрен күреп бара.* Н. Дәүли.

КЫР I *и.* 1. (Урманнан, авыл һәм шәһәр утырган җирдән аермалы буларак) урмансыз тигезлек, зур тигез ачык мәйдан. *Тулган ай үзенең моңсу нурларын урманнар, кырлар өстенә чәчеп әкрен генә йөзә.* Г. Әпсәләмов. *Безнең алда чит-читләре кара урман белән чикләнгән кыр күренеше ачылды.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Кырда булган, кырга урнашкан; кыр буйлап барган (юл турында). *Нәфисә, нидер исенә килгәндәй, кире борылып, кыр юлы белән менеп китте.* Г. Бәширов. || *с. мәгъ.* Үсемлекләр турында: бакчада үсми, кырда үсә торган; культуралашмаган, бакча үсемлеге булып саналмаган. *Кыр алмасы.* □ [*Искәндәр белән Мәрьям*] *актан киенгәннәр, башларында кыр чәчәкләреннән үрелгән такыялар.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Кошлар һәм хайваннар турында: кулга ияләштерелмәгән, йорт хайваны (кошы) булмаган; кыргый. *Кыр үрдәге. Кыр казы. Кыр аты. Кыр ишәге.* □ *Кыр хайванна-*

ры, ерткычлар үзләренең ояларына тулдылар. Г. Тукай.

2. Иген игү өчен эшкәртелә торган җир мәйданы; ашлык үстерелә торган мәйдан, басу. *Мин бит бу кыр, бу басуда сабан сөргән, тырма тырмалаган, утаулар утап, ураклар урган идем.* М. Гафури. *Сул кул якта аксыл бодай һәм солы кырлары, кояш нурлары астында ялтырап, дулкынланып торган төсле күренә иделәр.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Авыл хуҗалыгы культураларын үстерү белән бәйләнгән; игенчелек (кырчылык) белән бәйләнгән. *Кыр эшләре. Кыр станы. Кыр вагоны.* □ *Шат күңелле бу бабайны, Хәлим тәкъдиме буенча, колхоз идарәсе пионерларның кыр бригадасына агротехник итеп беркетте.* Г. Гобәй. || Нинди дә булса аерым бер максат өчен билгеләнгән участок, җир. *Нәфисә үзен шул тәҗрибә кырына беркетүне сорады.* Г. Бәширов. || Нинди дә булса эшләр башкарылган, нәрсәләрдер урнаштырылган яки нинди дә булса хәлгә дучар ителгән участок, урын. *Мина кырын үткәч, разведчиклар туп-туры тимер юл дамбасына юл алды.* Г. Әпсәләмов.

3. Нинди дә булса эш-хәрәкәтләр барган җир, урын (күбрәк сугыш хәрәкәтләре турында). [*Кыз*] *йөзе яралы кызылармеецны Алып чыкты сугыш кырыннан.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Сугыш яки поход шартларындагы хәрәкәтләргә, эшләргә бәйләнешле. *Кыр сугышы. Кыр госпитале. Кыр хезмәте уставы.*

4. *сөйл.* Спорт уены бара торган мәйдан. *Футбол кыры.* || Спорт әсбабының мәйданчыгы. *Шахмат кыры.*

5. *кит.* Территория, җир (эшрак күплектә кулланыла). *Совет кырларында туп ядрәләре соңгы мәртәбә яңырадылар да, еллар артыннан еллар үтте.* Һ. Такташ.

6. *күч.* Нинди дә булса бер эшчәнлек яки эш өлкәсе, сферасы. *Матур әдәбият мәсьәләсе Татарстан җөмһүрияте кебек автономияле җөмһүриятләр өчен бик зур эш кыры ул.* Г. Толымбай. || *шигъ.* Җәмгыять. *Бишъеллыкның бөек гигантлары һаман үсә, һаман күккә таба үрелә. Башларыннан инде сез яшәгән коммунизм кыры күренә.* Һ. Такташ.

7. *физ.* Нинди дә булса көчләрнең хәрәкәте, эшчәнлеге таралган пространство. *Магнит кыры. Кырның интенсивлыгы.*

Кыр билчәне *бот.*— оешма чәчәкләләр семьялыгыннан чәнечкеле чүп үләне; *русчасы:* осот полевой. *Иң әрсез чүп үләннәрдән каты билчән белән кыр билчәнен алырга мөмкин.* Ботаника. **Кыр бәрәңгесе** *бот.*— тамырында бүлбеләр булган күпьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* хохлатка. **Кыр зәгъфраны** *бот.*— тамыры бүлбегә охшаган көньяк үсемлеге; *русчасы:* крокус. **Кыр казы юлы** — *к.* Киек каз юлы. *Бераздан йолдызлар арасындагы кыйблага таба сузылган, сыеграк, киңрәк салават күпере шикелле булып, ап-пак, бормалы-бормалы Кыр казы юлы да беленде.* М. Гали. **Кыр какысы** — *к.* какы. *Чүп үлән булып саналган кыр какысы, кымызлык, кузгалак ишеләрнең күбесе бетерелде.* Соц. Тат. **Кыр капка, кыр капкасы** — басу киртәсенең капкасы, авылдан басуга чыга торган капка. *Уң якта басу киртәсе һәм кыр капкасы күренә.* А. Алиш. **Кыр кишере** *бот.*— мәксыманнар семьялыгыннан саргылт чәчәкле берьеллык үсемлек. **Кыр кынасы** *бот.*— *к.* кына I (1 мәгъ); *русчасы:* недотрога. *Күләгәле урыннарда --- бик кызыклы бер үсемлек — кыр кынасы (тидермәс) очрый.* Ботаника. **Кыр кәҗәсе** *зоол.*— боланнар семьялыгыннан кырда, урманда яши торган хайван. *Көтүче кыш көнендә урманда агач төбеннән берничә кыр кәҗәсе тапты.* Г. Тукай. *Боланнар, җайраннар, кыр кәҗәләре, кыр сарыклары сусызлыктан әлсерәп адаштылар.* И. Салахов. **Кыр күгәрчене** — күгәрченнәр семьялыгыннан зур булмаган урман кошы. **Кыр мәчесе** *зоол.*— Көньяк Америкада яши торган, тиресе сары таплы зур кыргый мәче. **Кыр сабыны** *бот.*— *к.* кырсабын; *русчасы:* огневик. *Чәчәгенең ике серкәче һәм биш таҗ яфракчыгы бар. Бу үсемлек кыр сабыны дип атала.* Робинзон әзл. **Кыр сарымсагы** *бот.*— суганчалылар семьялыгыннан тәме белән беркадәр бакчада үсә торган сарымсакны хәтерләткән кыргый үсемлек. **Кыр суганы** *бот.*— суганчалылар семьялыгыннан бакчада үсә торган суганга беркадәр охшаган кыргый үсемлек; *русчасы:* дикий лук. **Кыр сумкасы** — кыр шартларында гадәттә иңбаш аша асып йөртелә торган сумка (хәрби командирлар, геологлар, агрономнар һ. б. йөртә). [*Якупов*] *бодай башакларын өзеп алып, бармак битләрендә тәгәрәтеп карый да, кәгазьгә төреп, кыр сумкасына сала.* Г. Гобәй. **Кыр тавыгы** *зоол.*— тавыклар семьялыгыннан кыргый кош; көртлек. **Кыр тараканы** *зоол.*— коңгызлар семьялыгыннан авыл хуҗалыгы корткычларын юкка чыгара торган ерткыч бөҗәк; *русчасы:* жужелица. **Кыр тычканы** *зоол.*— тычканнар семьялыгыннан кырда яши торган кимерүче хайван (йорт тычканыннан көрән сыртында кара сызык булу белән аерылып тора). **Кыр чаганы** *бот.*— чаганның бер төре; *русчасы:* паклен. **Кыр чыпчыгы** *зоол.*— чыпчыклар семьялыгыннан кырда яши торган кошчык. **Кыр шпаты** *махс.*— силикатлар группасыннан бер минерал. *Кыр шпаты су һәм углекислый газ белән тәэсир итешә.* Анатомия. **Кыр ышыклау** — 1) кырларны җилләрнең зарарлы тәэсиреннән саклау өчен чаралар күрү; 2) *с. мәгъ.* кырларны җилләрнең зарарлы йогынтысыннан саклый торган. *Урмансыз районнарда агач утырталар, кыр ышыклау урман полосалары булдыралар.* Физ. география. **Кыр җитене** *бот.*— сыраҗлар семьялыгыннан зур чәчәкле бакча үсемлеге.

КЫР II *и.* **1.** *сөйл.* Нәрсәнең дә булса чите, кырые; тирәсе. *Өстәл кыры. Урман кыры.* □ *Абыстай кулындагы нечкә тал чыбык белән йөзлек кырына бәргәләп алды.* М. Гали. || Эшләпәнең бөкләнеп куелган кырые. *Аның башында киң кырлы эшләпә, өстендә җиңел сары плащ, аягында күн итек иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Предметта үзе кебек үк өслек белән почмак төзегән яссы өслек, ян. *Куб бертигез алты квадрат белән чикләнгән, алар аның кырлары дип аталалар.* Геометрия.

3. *иск. мат.* Геометрик фигураны чикләүче туры сызык. *Өчпочмак кыры.*

4. *с. мәгъ.* **кырындагы.** *сөйл.* Янындагы, тирәсендәге. *Кырындагын кырык ел эзләгән.* Әйтем.

5. *рәв. мәгъ.* **кырыннан** *сөйл.* Бер читтән, бер яктан. *Ходайбирде --- кырыннан гына Гөлҗиһанга карый иде.* М. Гафури.

6. *бәйл. функ.* **кырында.** *сөйл.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса янында.— *Тик кадерле ханчам кырында Корбан булсам икән юлында.* Ф. Бурнаш. *Яньчелгән, ярым ватык каскам ятып калды окоп кырында.* М. Җәлил.

7. *бәйл. функ.* **кырыннан.** *сөйл.* Яныннан, янына, кырыена. [*Гайнижамал:*] *Габдулла, менеп утыр абыең кырыннан.* Э. Фәйзи.

КЫРАГАЙ *с. диал.* **1.** Кырыс. *Кырагай табигатьле Иван Нилович участок начальнигы Смирновны әлеп алып селкеп салды.* М. Хәсәнов.

2. Кыргый.

КЫРА *рәв. диал.* Кискен, кискен итеп. *Кыра әйтү.*

КЫРАН: кыран да булмый (булмас) *диал.*— „бернәрсә дә булмый, бернәрсә дә булмас“ мәгънәсендә кулланыла.

КЫРАУ *и.* Гадәттә, язын һәм көзен төнлә яки иртәнгә табан температура 0°-тан түбәнгә төшеп, җир өстендә барлыкка килгән бәс, сыкы. *Салкыннар җиткәч, көзге кыраулар башлангач та, кабер өстендәге ал, кызыл, зәңгәр чәчәкләр шиңмәде.* А. Шамов. *Тышта кырау белән капланган ботаклар әкрен генә тирбәләләр.* К. Нәҗми.

Кырау алу (сугу, тию) — 1) кыраудан зарарлану, һәлак булу (игеннәр, яшелчәләр, җимешләр турында). *Карабодайны кырау алды, борчак, җир өстендә үк ярылып, орлыгын да кайтармады.* Г. Бәширов; 2) *күч.* зарар килү, юкка чыгу. *Чәчәк аткан яшьлегеңә Көзге кырау тимәсен.* Ә. Ерикәй. **Кырау төшү** — 1) җир өстендә кырау барлыкка килү. *Берничә көн рәттән иртән түбәләрне һәм чирәмнәрне агартырлык булып кырау төште.* М. Гали; 2) *күч.* зарар килү; көче бетү. *Башыңа сырхау килсә, кесәңә кырау төшә.* Мәкаль. *Агарса да чәчләр көмеш кебек, кырау төшмәс безнең йөрәккә.* М. Җәлил; 3) *күч.* агару; чалара башлау. *Сакалга кырау төшү.* □ — *Кара инде, чәчләреңә кырау төшкән бит.* Р. Ишморат.

КЫРАУЛАНУ *ф.* 1. Кырау төшү.

2. *күч. сөйл.* Агару, чалару. *Галиәкбәр абзый кыраулана башлаган куе кара мыегын сыпыра-сыпыра болай диде.* И. Туктар.

КЫРАУЛЫ *с.* Кырау төшкән. *Кыраулы төннәр.* || Кыраудан бәсәргән, сыкыланган. [*Бай:*] *Куркыныч бит, кышны сезчә кышласаң. Ул кара көзнең кыраулы кырлары, Чиркәнеч һәм вак, суык яңгырлары!* Г. Тукай. *Көз иде... Җирнең шушындый Күңелсез чагы иде, Астралар, гөлләр кыраулы, Каеннар сары иде.* Х. Туфан.

КЫРАЧ *с.* Нык тәэсир итә торган; үзәккә үтә торган, салкын һәм кискен (җил турында). *Әмма җәйнең әссе кояшында көеп, көзнең кырач җиледә өтелгән, янып торган кызгылт-көрән битле, ялкын чәчрәтердәй үткен күзле бу яшь киекләрдән* [*кызлардан*] *бетмәс-төкәнмәс яшьлек дәрте бәреп тора.* Г. Бәширов.

КЫРГАВЫЛ *и. иск. к.* фазан. *Кызым баласы — кыргавыл.* Әйтем.

КЫРГАВЫЧ *и. диал. к.* кыргыч 1. [*Нургали сыер савучыларга:*] *Бүген үк, сыерларыгызны кояшка чыгаргач, себерке, кыргавычлар белән коралланасыз да һәммәсен дә ялт иттереп куясыз.* Ә. Еники.

КЫРАША *и. диал.* Төче суда яши торган балык. *Салих... кармактан каралҗым-яшькелт озын кыраша ычкындырып күпергә ыргытты.* Г. Мөхәммәтшин.

КЫРГАЯК *и.* Буынтыгаяклылар классыннан юеш урыннарда үрчи торган күп аяклы бөҗәк. *Кышкы көннәрдә кайнар кер суы парыннан тәрәзәләр елый, чатлыклар юешләнә, кыргаяклар тагын да арта.* А. Шамов.

КЫРГЫЗ *и.* 1. Кыргызстанда яши торган төп халыкның атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. *Кыргызлар Совет власте елларында тулысынча утрак тормышка күчтеләр.* СССРның экон. геогр. || *с. мәгъ.* Кыргыз халкына караган, кыргыз халкына бәйләнешле. *Кыргыз теле. Кыргыз җырлары.*

2. *иск.* Октябрь революциясенә чаклы казах халкын да шулай атап йөрткәннәр. *Шәкертләрнең кайберәүләре кыш уртасыннан башлап кыргыз арасына тарала башлаганга күрә, самовар куйдыручылар да азая башлады.* М. Гафури. [*Газизә:*] *„Тургайдан килгән кыргыз сәүдәгәре Кунарбай“,— диде.* Ә. Фәйзи.

КЫРГЫЗЧА *рәв.* Кыргыз телендә. *Кыргызча сөйләшү.* || *иск.* Казах телендә, казахча. [*Газизә:*] *Кыргызча сөйли ул. Тора-бара үзең дә аңлый башларсың әле.* Ә. Фәйзи.

КЫРГЫЗЧАЛАШТЫРУ *ф. сөйл.* Кыргызчага тәрҗемә итү, кыргыз теленә күчерү.

КЫРГЫЙ *с.* 1. Кулга ияләштерелмәгән, йорт хайваннарыннан аермалы буларак, иректә яшәүче (хайваннар һәм кошлар турында). *Кыргый кошлар. Кыргый хайваннар.* □ *Үзәк Азиядә кыргый дөя һәм кыргый ат яши, алар башка якларда бер җирдә дә юк.* Дөнья кис. геогр.

2. Культуралаштырылмаган, бакчада үстерелми торган (үсемлекләр һәм аларның җимешләре турында). *Кыргый алма.* □ *Борынгы кеше кыргый үсемлекнең ашарга яраклы орлыкларын һәм җимешләрен, тамыр һәм сабакларын җыйган һәм шуның белән тукланган.* Ботаника.

3. Кеше кулы тимәгән, әшкәртелмәгән; кешеләр яшәмәгән. *Кыргый дала.* □ *Чокырның тирә-ягы кыргый куаклыклар белән томаланган.* Г. Гобәй.

4. Культура үсешенең иң түбән баскычында торган; борынгылык дәверенә караган. *Кыргый кабиләләр.* □ *Бигрәк тә кыргый халыкларның тормышы, аң һәм фикер йөртүләре турында сөйләнгән сүзләр тыңлаучыларны бик нык тартты.* Ш. Камал. || *и. мәгъ.* Культура үсешенең түбән баскычында торган кабиләгә кергән кеше; вәхши. *„Кыргый“, сугышчы һәм аучы, йортта хатын-кыздан кала икенче урынны тоту белән канәгатьләнгән.* Ф. Энгельс.

5. *күч.* Вәхши, кешелексез, шәфкатьсез. *Кыргый фашистлар.* || Тупас, начар. [*Гөлзадә Фазылга:*] *Синең хатын-кызларга карата бабайлардан калган кыргый карашыңны яратмыйм.* Р. Ишморат.

6. *күч.* Кешеләр белән аралашырга яратмый торган; тартынучан, оялчан. *Үзе кыргыйрак кеше булса да, Мөхетдин карт та мине ярата.* М. Гали. || *и. мәгъ. сөйл.* Шундый сыйфатка ия булган кеше. *Әгәр Хәйдәр ялгышмаган булса, бу кыргыйның озын керфекләре арасында үчекләү очкыны да чәчрәп китмәде микән әле.* Г. Бәширов. || *рәв. мәгъ.* Кешеләр белән артык аралашмыйча, кешеләр белән артык катнашмыйча. *— Мин бер мишәр улы кыргый үскән, ә син күрше чуваш халкыннан.* Һ. Такташ.

7. *күч.* Котырынкы, ярсулы, тыелгысыз. *Кинәт Газинурның йөрәгән кыргый бер ярсу һәм шатлык биләп ала.* Г. Әпсәләмов. *Кыргый тавыш белән сөрән салып, басу капкасыннан кораллы отряд килеп керде.* К. Нәҗми. || Чиктән тыш, сәер, гадәттән тыш. [*Әптелбәр*] *шулай ипташларе белән беренче кар шатлыгын бүлешә, үзенең кыргый сикереңүләре белән бу кышта аның да хакы барлыгын аңлатырга тырыша иде.* Ә. Фәйзи.

8. *күч. махс.* Нинди дә булса оешмага кермәгән, нинди дә булса бер оешмага берләшмәгән; монополиягә кермәгән, монополиягә берләшмәгән. *Кыргый артельләр. Кыргый предприятиеләр.* □ *Монополияләр монополистик берләшмәләргә кермәүче „чит“, „кыргый“ предприятиеләрне буу өчен бөтен чараларны күрәләр.* Политэкономия.

Кыргый киндер *бот.*— басуда үсә торган чүп үлән; тарма. **Кыргый мәк** *бот.*— коелган орлыктан үсеп чыккан мәк. **Кыргый мәче** *зоол.*— мәчесыманнар семьялыгыннан ерткыч хайван, селәүсен. *Тиен, кыргый мәче, шулай ук Себер тайгасында яшәүче борындык һәм кеш агачлар буенча җирдәге кебек йөгерәләр.* СССР физ. геогр.

КЫРГЫЙЛАНУ *ф.* 1. Кыргыйга әйләнү; табигый хәленә килү.

2. *күч.* Кешеләр белән аралашмый башлау, бик тартынучан (оялчан) булып китү. *Бөтенләй кыргыйлану.*

КЫРГЫЙЛАРЧА *рәв.* 1. Кыргыйлар кебек, кыргыйларда булганча, кыргыйлар гадәтенчә.

2. *күч.* Тупас, каты, вәхшиләрчә.

КЫРГЫЙЛАШУ *ф. сөйл. к.* кыргыйлану.

КЫРГЫЙЛЫК *и.* **1.** *махс.* Борынгы культура баскычында булу (кабиләләр һәм халыклар турында). *Кыргыйлыкның урта баскычында барлыкка килеп һәм аның югары баскычында үсүендә дәвам итеп, ыруг --- варварлыкның түбән баскычында үзенең чәчәк атуына ирешкән.* Ф. Энгельс.

2. *күч.* Вәхшилек, шәфкатьсезлек, кешелексезлек. *— Сугыш дигәнең, адәм баласының иң нечкә, иң мөкатдәс тойгыларын мыскыл итеп, кемдер әйтмешли, канлы итеге белән пычракка салып таптый. Коточкыч кыргыйлык бит инде ул.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Культурасызлык, тәртип-культура нормаларын белмәү һәм үтәмәү. *Ул арада булмый, бүтәннәре ташланып ике егетне тагын аерырга тотыналар, тагын китә көрмәкләшү, йолкышу, акыру, сүгенү... Бу нинди кыргыйлык бу? — Һич аңламассың.* Ә. Еники.

КЫРГЫН *и.* **1.** *иск.* Кешеләрнең күпләп кырылуы, үләт. *Түрә симерсә, кыргын килә.* Әйтем.

2. *диал.* Күп кешеләр, күп кешеләр төркеме.

КЫРГЫЧ *и.* **1.** Атны чистарту өчен хезмәт итә торган тимер щетка. *Газинур, җиңнәрен сызганып, кулына кыргыч, щетка алып, бәйдәге атлар янына килде.* Г. Әпсәләмов. || Гомумән, нәрсәне дә булса чистарту, шомарту яки кыру, кырып алу өчен корал, җайланма. *Борынгы кешеләр --- тире чистарту өчен кыргычлар --- ясарга өйрәнгәннәр.* Борынгы зам. тарихы. *Зырлый кыргыч — цех яңгырата, Кызлар фетр шомарта.* Ш. Маннур.

2. *тех.* Нефть скважинасын парафиннан арындыра торган җайланма. *Хәзерге кебек, автомат кыргычлар, автомат япкычлар, скважинаның хәлен ерактан ук хәбәр итеп тора торган диспетчерлык системасы берсе дә юк иде әле ул чакта.* Р. Төхфәтуллин. *Шушы көнне генә аның бер скважинасында чыбыгы-ние белән парафин кыргыч өзелеп забойга төшеп китте.* Ш. Бикчурин.

3. Аш-су әзерләгәндә яшелчәләрне кыру, ваклау өчен җайланма. *Керәнне кыргычта кыру.*

КЫРГЫЧЛАУ *ф.* **1.** Кыргыч белән [атны] чистарту. [*Тимербай:*] *Атларны да кыргычлап, чистартып, коендырып кайтырга кирәк.* М. Гали. [*Җәләл:*] *Безгә җигеләсе атлар кыргычланганмы?* Г. Ибраһимов.

2. *тех.* Чистарту, нәрсәдән дә булса арындыру. *Скважинаны кыргычлау.*

КЫРДАШ *и.* **1.** Кем белән дә булса бер кырда яки күрше кырда, басуда эшләүче кеше.

2. *геом. иск. к.* эргәдәш. *Кырдаш почмаклар.*

КЫРКА *рәв. диал.* Кискен, кискен төстә. *Кырка эш итү.*

КЫРКУ I *ф.* **1.** *сөйл.* Нәрсәне дә булса кисү, киселеп җыйнаклау (мәсәлән, үләнне, чыбыкны, ботакларны). *Каен ботакларын кыркырга кирәк иде,— дип уйлап алды ул, аларның тәрәзәгә өзлексез килеп бәрелүләренә борчылып.* А. Шамов. || Урак яки урак машинасы белән ашлык уру турында. *Дүрт ат җигелгән урак машинасы (лобогрейка), өч-дүрт гектар чамасы бер күләм җирне уратып, өзлексез зырылдаган тавыш чыгарган хәлдә, кыркып бара.* Ш. Камал.— *Миһриҗамал туташ, дигән була, быел арыш озын бит, билеңне авырттырма, өстеннәнрәк кырыксаң да ярар.* М. Гали.

2. Сарык, куй һ. б. ш. хайваннарның кайчы яки машина белән киселеп йонын алу. [*Кыр кәҗәләренең*] *йонын да көтүче үзе кыркачак, сөтен дә үзе савачак.* Г. Тукай. *Нинди генә эш бирмәсеннәр, берсен дә кире какмады ул: кер дә уды, чүп тә утады, сарык та кырыкты.* И. Гази. || Атларның ялларын, койрык кылларын тигезләп яки билгеле бер рәвешкә китереп кисү. *Икенче яшькә чыкканда, бездә яз көне тайның ялын, койрыгын бөтенләй кыркалар: „кырыкмыш“ ясыйлар.* Г. Ибраһимов.

3. *сөйл.* Чәчне төбеннән үк алдыру, кырдыру.— *Юк, чәчне кырыкмаска, аны кәләпүш һәм бүрек астына яшереп, абзыйны каршы алырга.* Ә. Фәйзи. *Җидесе дә [кызларның] егет булып Киенгәннәр бер заман, Җидесе дә чәчен кыркып, Ир булганнар бераздан.* Бәет. || *иск.* Сөннәт кушканча кырып яки кырдырып, сакалга, мыекка билгеле бер рәвеш бирү, сакал-мыекны төзәтү. [*Шкафчы:*] *кем дә кем мөселманча итеп, менә шуның шикелле кызыл төймәле казакилар кисә, башына ак бүрек кисә, мыегын сөннәтчә итеп кыркып йөртсә --- менә шул кеше чын әдәпле кеше булыр.* Г. Камал.

4. *күч. сөйл.* Даими рәвештә талау, берәр кеше исәбенә яшәү. *Мәмләкәттә гаскәрләрдән башка берәү дә жалованье алмый; сарай маэмүрләре әмирнең бүләкләре илә яшиләр: башкалары халыкны кыркү белән яшиләр.* Шура.

КЫРКУ II *с.* **1.** Артык тозлы; артык әче, артык ачы (аш һ. б. ш. турында). *Кырку кымыз. Кырку катык.* □ [*Хәерниса:*] *Киленкәем, ашның тозын карый күр, бик кырку була күрмәсен.* Г. Ибраһимов. || Артык көчле, ник тәэсир итә торган, борын яргыч (мәсәлән, ис). *Итегенә бәрелеп барган әче әремнең кырку исе аның борынына килеп керде.* И. Гази. *Бу якта кырку сандык исе килеп тора.* Р. Төхфәтуллин.

2. *күч.* Усал, кырыс; кызу канлы, тиз кабынып китүчән. *Хабул абый кырку кеше иде.* Х. Туфан. [*Халиков:*] *Аның характерында минус яклар да бар. Кырку табигатьле кеше.* А. Расих. || *рәв. мәгъ.* Кырыс итеп, кырыс рәвештә. *„Син анда, Фатих, ниндидер мөгез чыгарырга маташасың, имеш“,— дип башлады ул, кырку гына.* Ф. Хөсни. *Мин, нишләптер, кырку гына итеп аңардан: „Сез кайда укыган идегез?“ — дип сорадым.* А. Таһиров.

Кырку ачы — аеруча ачы тәмдәге. *Тәм сизү [органы] төрлечә төзелгән, шуның аркасында кешедә дүрт төрле тәм сизү тойгысы булырга мөмкин, һәм шулар буенча ул әче, кырку ачы, татлы һәм тозлы әйберләрне аера.* Анатомия.

КЫРКУЛАНУ *ф.* **1.** Озак кайнау аркасында артык тозлыга әйләнү, ачы тәм керү (аш турында). [*Гөлбану:*] *Күптән аш вакыты җиткән, ашым кыркуланып бетә инде, һичбер вакытында ашау юк, эчү юк, сату да сату.* Г. Камал.

2. Артык әчеләнү, артык әчегә әйләнү (сыра, бал һ. б. турында). *Сыра кыркуланы.*

3. *күч.* Кырыслану, кырыска әйләнү, җитдиләнү, усаллану. *Кара сакаллы, агарынган һәм чырае бераз кыркулана төшкән матур йөзле икенчесенең күкрәк турысыннан кан типкән.* Г. Бәширов.

КЫРКУЛЫК *и.* **1.** Артык тозлылык; артык ачылык, артык әчелек (аш һ. б. ш. турында). *Шулпаның кыркулыгы.*

2. *күч.* Кырыслык, усаллык, кызу канлылык. *Холыкның кыркулыгы.* □ *Редактор буларак, үз сотрудницына бу мәсьәләдә берничек тә ярдәм күрсәтә алмавын да сизә иде булса кирәк, кыркулыгы озак бармады.* Ф. Хөсни.

КЫРКУЧЫ *и.* Сарык йонын алучы; тире йонын кырка торган эшче. *Мехкомбинатта скорняк-машинистка Рәкыя Әхмәтҗанова һәм кыркучы Мария Батаева үзләрен яхшы яктан күрсәттеләр.* Соц. Тат.

Кыркучы тимерәү *мед.*— тирене зарарлый торган йогышлы гөмбәчек авыруы; *русчасы:* стригущий лишай.

КЫРКЫЛДАУ *ф. сөйл.* Өзек-өзек авазлар чыгару, чыркылдау (тавыклар, кошлар турында). *Барсы кыркылдый тавыктай.* Г. Тукай.

КЫРКЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* кырку I. *Авылда минем тайның болай матур кыркылуын күргәч, малайлар таң-хәйранга калдылар.* Г. Ибраһимов.

2. Ышкылудан тузу, тузып бетү. *Җиң очлары кыркылу.*

КЫРКЫЛЫК *и. диал.* Сарык йонын ала торган зур кайчы, сарык кайчысы.

КЫРКЫЛЫШУ *ф. диал.* Сатулашу, артык ник сатулашу. *Бер тиен өчен дөнья хәтле кыркылышып, сатулашып кына ала Гобәйдуллиннар.* Г. Тукай.

КЫРКЫН *и. иск.* Кол кыз, кәнизәк, җария. *Кыз чагында ук ят сарайларда кыркын — кәнизәк булып калучы кызлар килеп чыкканын аңларга юл ачыла.* Каз. утл.

КЫР-КЫР *аваз.ияр.* Кайбер кошларның кыркылдавын, чыркылдавын белдерә.

КЫРКЫРЫЙ *и.* Әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан терлек ашамый торган үләнчел үсемлек (*к.* очкылык үләне); *русчасы:* икотник.

КЫРКЫТУ *ф. Йөкл. юн. к.* кырку I.

Кыркытып алдыру — чәчне алдыру (машина яки кайчы белән). *Машина белән кыркытып алдырган кара чәчле, карасу күзле, матур төз борынлы, коеп куйган шикелле ник гәүдәле, егерме алты, егерме җиде яшьләрендәге егет — котлауларга җавап бирү өчен урыныннан торды.* А. Шамов.

КЫРКЫШУ *ф.* **1.** *Урт. юн. к.* кырку I (1, 2 мәгъ.).

2. *диал.* Сатулашу, кыркылышу. *Әти бик озак сатулашып, бик ник кыркышканнан соң гына, кәҗәне ике сум егерме биш тиен көмешкә сатып җибәрде.* М. Гафури.

КЫРЛАНГЫЧ *и. иск. к.* карлыгач.

КЫРЛАУ *ф.* Кырлар (II, 2 мәгъ.) ясау, кырлы итү. *Камчыларын кырлап үргән, Тармакларын кыллап үргән.* Ш. Маннур. || Кырып һәм шомартып, ташка (пыялага, металлга) кисешә торган яссы өлекләрдән торган форма бирү. *Алмаз кырлау. Хрусталь кырлау.*

КЫРЛАЧ I *и. иск.* Кышның иң салкын ике аеннан гыйбарәт сезон (декабрь — январь). *Татар халык фольклорында Ай-кояш календаре айларының түбәндәге исемнәре сакланып калган:* **1.** *Агам яки ага кырлач ае (хәзерге календарь буенча — декабрь);* **2.** *Энем кырлач ае (январь).* Сов. мәк.

КЫРЛАЧ II *и. бот.* **1.** *к.* кырлыган. *Чөгендер борчасына каршы көрәшү өчен иң элек борча үрчи торган чүп үләннәрне (алабута, кырлач һәм башка үләннәрне) утарга кирәк.* Җиләк-җимеш...

2. Карабодайсыманнар семьялыгыннан кайбер чүп үләннәрнең исеме составында очрый торган сүз. *Уралмалы кырлач. Пәрәвез кырлач.*

КЫРЛАЧ III *и. диал.* Җир сөргәндә, тырмалаганда, ашлык урганда яки печән чапканда, кайбер урыннарда эшкәртелми калган кечкенә аралык, чи калган җир. *Сукалаганда кырлач калдырырга ярамый.*

КЫРЛЫ: кырлы борчак *бот.* — борчаклар семьялыгыннан бөртеге терлек азыгы итеп кулланыла торган үсемлек; *русчасы:* чина. **Кырлы куга** *бот.* — чәчәге себеркәч яки чуклы булган үләнчел үсемлек, сусын; *русчасы:* касатик.

КЫРЛЫГАН *и. бот.* Кырлыганнар семьялыгыннан зур чәчәкле озын үлән (әлекке заманда кайбер чакларда чәй урынына кулланганнар); *русчасы:* кипрей, иванчай. *Киселгән, бигрәк тә янган урманнарда кырлыган беренче булып үсеп чыга.* Робинзон әзл.

КЫРЛЫК *и.* **1.** Канәферсыманнар семьялыгыннан бик әрсез чүп үләне; *русчасы:* торица. *Бакра чәчкән кырлык урыр.* Мәкаль. || Шуның орлыгы, ул тары, җитен орлыгына бик охшый, шул сәбәпле аны ашлык бөртекләреннән аерып алуы бик кыен.

2. *сөйл.* Ашлыкта була торган һәм аннан аерып алына торган чүп үләннәрнең орлыклары. *Фермага бер йөк кырлык илттем.*

3. *диал. к.* кырлыган.

КЫРЛЫКУРА(Й) *и. бот.* Чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан сабагы кырлы булып үсә торган көпшәдән гыйбарәт сары чәчәкле үләнчел үсемлек; *русчасы:* пастернак луговой. *Бу чакта --- мин кыр өстеннән башларын чыгарып торган кырлыкурайларның, җил белән селкенеп, ниндидер моңлы тавыш чыгаруларына карап утыра идем.* М. Гафури.

КЫРЛЫ-МЫРЛЫ *с. сөйл.* **1.** Бер болай, бер тегеләй; төрлечә, каршылыклы (сүз, сөйләшү турында). || Төрлечә аңлашыла торган, икенче төрле булып та аңлашыла торган. | *рәв. мәгъ. Кырлы-мырлы сөйләү.*

2. *рәв. мәгъ.* Бик төксе, коры; кечелек күрсәтмичә (мөгамәлә, тәртип, кыланыш турында). *Кырлы-мырлы тору.*

КЫРЛЫ-СЫРЛЫ *с. сөйл.* Сырлы-сырлы булып торган, сырланган. [*Нәфисә*] *бала чагыннан ук таныш булган кырлы-сырлы вак кына хәрефләргә күзе төшүгә дулкынланып хатны укырга кереште.* Г. Бәширов.

КЫРМА I *с.* Кыркылган, кыркып кыскартылган. *Кырма сакаллы, җеп мыеклы --- авыл старостасы Зариф эчү, сыйлану ягын гына кайгырта.* Г. Толымбай. || Кырылганнан соң үсеп чыккан. *Садыйк кырма сакал баскан йөзен шартлаган якка борды.* А. Алиш.

Кырма бүрек — кыска цилиндрик формалы, түбәсе яссы булган колакчынсыз каракүл бүрек. *Баштагы кырма бүрек, яңа калыптан алган кебек, бераз кырынрак, назлатып киелә.* Г. Ибраһимов.

КЫРМА II *и. иск., диал.* Трахома (күздә була торган йогышлы авыру).

КЫРМАВЫК *и. диал.* **1.** *к.* тигәнәк. *Кәҗәгә кырмавык ябышу.* □ *Кырмавык кебек чәнчеп торучы курку тойгысыннан шомланып уянган төннәрнең берсендә, аның башына бер уй килде.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Начар як, начарлык, кимчелек. *Алар арасында шагыйрьнең күңелен тырнаган кырмавыклар да байтак булган.* Г. Халит.

КЫРМАЗЫЙ *с. иск.* Кызыл, кызыл төстәге.

КЫРМЫСКА *и.* **1.** Элпә канатлылар семьялыгыннан бер оя (төркем) булып яши торган бөҗәк. [*Хәйдәр*] *агач кайрысына чигелгән серле әзләр, үзеннән зур ботак кисәге күтәреп йөгерүче кырмыскалар һәм бүтәннәр тормышы турында, кайда утыруыңны онытырлык итеп, мавыктыргыч хикәяләр сөйли.* Г. Бәширов. *Зур башлы кызыл билле кырмыскалар нәрсәнедер сырып алганнар.* А. Алиш.

2. *күч. сөйл.* Кешеләр турында: күзгә артык бәрелеп тормаган, ләкин тырыш, эшчән кеше; эшләп торган кеше.

Кырмыска иләве — *к.* кырмыска оясы. **Кырмыска оясы** — 1) кырмыскаларның җир өстеннән өем булып чыгып торган, туфрактан, ылыстан яисә вак-вак чыбыктан гыйбарәт торагы. *Бу эш, кырмыска оясына таяк тыгып бутаган кебек, бөтен авылны гөж китерде.* М. Гафури; 2) *күч.* кешеләр күп булган урын, кешеләр кайнашып торган урын. *Ул минем беренче сүземдә үк бу халыктан, бу кырмыска оясыннан котылырга риза булды.* Г. Ибраһимов. **Кырмыска түмгәге** — *к.* кырмыска оясы. [*Гөлбану:*] *Кем булса да игелек күрә алмас. Кырмыска түмгәгенә төшкән елан шикелле үрле-кырлы сикерер.* Г. Камал.

КЫРМЫСКААШАР *и. зоол.* Тропик Америкада яшәүче, күбрәк кырмыска һәм термитлар белән туклана торган имезүче хайван. *Кырмыскаашарлар озын тел-*

ләре белән биредәге кырмыскаларны һәм термитларны ашыйлар. Дөнья кис. геогр.

КЫРПА I *с. сөйл. к.* кырпу (1 мәгъ.), кырпулы. — *Шайтангамы сезнең кырпа бүрек, Кыска чалбар, читек-кәвешләр.* Һ. Такташ.

КЫРПА II *и. диал. к.* кырпак.

Кырпа төшү — *к.* кырпак төшү. *Ханов --- хәтсез сирәгәйгән, кырпа төшкән чәчләрен сыпырып куйды.* С. Рафиков.

КЫРПАК *с.* 1. Вак, вак бөртекле (кар, кар бөртеге турында). *Чиркәү янындагы ак бәсле агачлар катыннан узганда Якуп бер агачны тотып селекте. Өстенә кырпак кар коелды.* И. Гази. *Тышта кырпак кар төшкән иде.* М. Гафури. || Юка гына һәм көпшәк (вак кына кар явып барлыкка килгән катлау турында). *Пычрак җир йөзе яңа яуган кырпак кар белән ак ефәккә чолгангандай матур сыйфат алган.* Г. Ибраһимов.

2. *и. мәгъ. сөйл.* Вак кар явып барлыкка килгән юка гына кар катлавы; беренче вак кар. *Көннәр тагын да суыта төшеп, инешләргә боз ката, җиргә кырпак төшә.* Г. Бәширов.

◇ **Кырпак төшү** — агару, чалару (чәч һ. б. ш. турында).

КЫРПУ *и.* 1. Нинди дә булса киемнең, күбрәк баш киеменең читенә тотылган мех. *Яка кырпуы.* || *с. мәгъ.* Мех тотылган, читенә мех куелган, кырпулы. [*Габдулла*] *Вафаның кырпу бүреген сорап алды.* Ә. Фәйзи.

2. *сөйл.* Эшләпәнең чите, кырые. *Мулла аның пычранган чабаталарына, куна кебек киң аркасына һәм кырпуы чачаклана башлаган киез эшләпәсенә ачуланып карап алды.* А. Шамов. || Гомумән, нәрсәнең дә булса чите, кырые.

КЫРПУЛАУ *ф.* Нинди дә булса киемнең, күбрәк баш киеменең кырыена мех тоту, кырпу тоту. *Бүрекне кырпулау.*

КЫРПУЛЫ *с.* Мех тотылган, читенә озын тар мех тегеп куелган. [*Көрәшчеләрнең*] *кайберләре ак киез эшләпәдән, кайберләре кырпулы бүректән, кайберләре түбәтәйдән генә иделәр.* М. Гали. *Саимә бу көйдергеч сүзне шундый ачу белән әйтте, Камалиның баш тиресе, камчат кырпулы бүреге астында керпе йөргән кебек, чәнчеп берьюлы кубып киткәндәй тоелды.* К. Нәҗми.

КЫРПУСЫЗ *с.* Мех тотылмаган, кырпуы булмаган. *Кырпусыз бүркен басып киеп, тула оек өстеннән чабата кигән тәбәнәк бер кеше --- кычкырды.* М. Галәү.

КЫРПЫ: кырпы балыгы — мәрсин балыклары семьялыгыннан булган иң зур балык; белуга. *Һәр ел боз астыннан тотылган кырпы һәм осетр балыкларын --- тере килеш патша сараена илтәләр.* Ә. Фәйзи.

КЫР, КЫРР-КЫРР *аваз иляр.* 1. Бака һ. б. ш. кычкырган тавышны белдерә.— *Кайчагында кичләрен „кырр" итеп акрын гына сузып кычкырган бака тавышы ишетелә торган иде.* Ш. Камал.

2. Йөткерү-какыру тавышын белдерә. *Йөткерә чехотка күк кырр! кырр!* Г. Камал.

КЫРРЛАУ *ф. сөйл.* Кычкыру (тавык турында). *Күзләрен әйләндереп салган тавык кыррлап кычкырып җибәрде.* Г. Толымбай.

КЫРТ I *рәв.* Кинәт, капыл; бик тиз. *Яңа салынган бер агач күпергә җитәрәк, машина кырт тукталды.* И. Гази.

◇ **Кырт киселү (өзелү)** — кинәт өзелү, бүленү (сүз, сөйләү турында). **Кырт кисеп** — катгый рәвештә, катгый итеп. *Яңа директорның болай кырт кисеп куюыннан уңайсызланган Василий Степаныч машинасын караңгы тыкрыкка борды.* Г. Әпсәләмов. || **Катгый рәвештә** әйтеп; кисәтеп. *Бер аулакта мин аңа кырт кисеп куйдым.* А. Шамов. **Кырт кисү, кырт кистерү** — 1) туктату, кинәт бүлү, өзү (сүзне, сөйләүне). *Ул — Һиммәтовның сүзен кырт кисте.* Х. Кәрим; 2) катгый һәм кыска җавап бирү. *Нәүбәтче кыз кырт кисте: „Мөмкин түгел",— ди.* Г. Ибраһимов.

КЫРТ II *аваз иляр.* Нәрсәне дә булса кайчы, пычак белән кискәндә яйсә жеп һ. б. ш. нәрсәләр кинәт өзелгән вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Кырт итеп кисеп ташлау.*

КЫРТ-КЫРТ *аваз иляр.* 1. Нәрсәне дә булса чәйнәгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Атның кырт-кырт ашавыннан һәм сирәкләп пошкыруыннан башка бер тавыш та юк.* М. Гафури. *Кырыкмыш лапас астында һаман да кырт-кырт иттереп бик салмак кына печән ашый.* М. Гали.

2. Тавык кыртлаган тавышны белдерә.

КЫРТЛАТЫП *рәв.* Кырт иткән тавыш чыгарып, кырт иттереп. *Кыртлатып кисү.*

КЫРТЛАУ *ф.* 1. Тавык һәм башка кайбер кошлар турында: кыска-кыска гына итеп тавыш бирү, өзек-өзек авазлар чыгару. [*Хәкимҗан:*] *Элек тавыклар кыртлый иде, хәзер әтәчләр кыртлый башлады.* К. Әмири.

2. Йомырка салудан туктап, йомырка басар хәлгә килү билгесе буларак, тавыкның өзек-өзек авазлар чыгаруы турында (бу вакытта тавык һәрвакыт кыртлап йөри). *Чуар тавык кыртлавыннан бизмәде, һаман-һаман утырырга оя эзләде.* А. Алиш.

КЫРТЫМ *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан май алу өчен игелә торган берьеллык үләнчел үсемлек; *русчасы:* сафлор.

Кыртым мае — шул үсемлекнең орлыгыннан алынып, азык итеп һәм техник максатлар өчен кулланыла торган эфир мае.

КЫРТЫШ *и.* 1. Такта ярганда бүрәнәнең ике кырыенда кала торган бер ягы киселмәгән такта; *русчасы:* горбыль. *Склад эшкә яраклы кыртыш сата.* Соц. Тат.

2. *диал.* Яру өчен уңайсыз, катлаулары борылмалы булып үскән яки күп ботаклы агач кисәге. *Бу кыртышны ярып булмый.* □ *Әле дә яхшы сукмады, кыртыш белән тукмады.* Такмаза.

3. *диал.* Җирнең үлән үскән иң өске катлавы, кәс. *Кыртыш сөрү.*

4. *диал. к.* шыртлака. *Менә бәхет, әләктә нәни кыртыш бер балык.* Ә. Бикчәнтәева.

КЫРУ I *ф.* 1. Нәрсәнең дә булса өске катлавын чистарту, берәр ябышкан нәрсәдән арындыру. *Рабига да идән сайгакларын, сәке такталарын гәрәбә кебек ялтыраганчы кырып юды.* К. Нәҗми. *Марат камырлы кулын пычак белән кыра-кыра чыгып килгән Зифага әз генә баш иеп алды.* Г. Гобәй.

2. Чәчне, сакал-мыекны һ. б. ш. пәке белән төбеннән үк кисү, кисеп алу. *Сакалны кырганда борыласарыла бөтәрләнеп йөргән парикмахерның итенешләре безгә бик ошады.* Һ. Такташ. || Билгеле бер рәвеш бирепкыру, төзәтеп кыру (мәсәлән, сакалны, мыекны). *Шул колак эченнән әллә нинди сары бишмәтле итчеләр, кырган мыеклы мөритләр, кәвешче-итекчеләр коела башлады.* Г. Тукай.

3. Төптән үк кистереп чабу (үләннәрне чалгы белән).

4. Өске катлауларын махсус станокта кистерә-кистерә металлны яки агачны билгеле бер формага китерү, аларга билгеле рәвеш бирү. *Фрезер станоклары үзләренең үткен тешләре белән тимерләрне кырып, кирәкле хәлгә китерәләр.* А. Алиш. *Анда берничә колхозчы, тәгәрмәч бүкәннәрен кырып, тугымнар эшләп, колхоз арбаларына тәгәрмәчләр һәм күчәрләр ясап яталар.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Металлны һәм

агачны кыру юлы белән механик эшкәртүгә бәйләнгән; кыру өчен хезмәт итә торган. *Кыру эше. Кыру станогы. Кыру мастерское.*

5. Кыргычта яки башка нәрсәдә ышкып ваклау, вак кисәкләргә әйләндерү (яшелчәне). *Бәрәңге кыру.* □ *Суган әрчү, Кишер кыру синең эшеңме?* З. Мансур.

6. Тирене зарарлау (күбрәк аяк турында). *Ботинка үкчәне кырган.* || *күч.* Борчу, борчу хисе уяту, тыныч-сызлау. *Һәммәсе --- Хәятның йөрәгенең әллә кайсы җирен кырып торалар иде.* Ф. Әмирхан.

7. *тар.* Хәрби хезмәткә яраклы дип табып, солдатка алу (электә хәрби хезмәткә яраклы дип табылганнарның чәчен кырудан килеп чыккан мәгънә). *Зыя алынган, „мәхдүмне яңадан кырганнар" иде.* Г. Ибраһимов.

◇ **Кырган да борган** — нинди булса эшнең бер кеше өчен тәмамланган, беткән саналуы яисә нәрсәнең дә булса әзер исәпләнүе турында әйтелә. [*Олаучы абый:*] *Синең эш кырган да борган.* Ә. Фәйзи. **Кырып ташлау** — фикерне, уйны һ. б. ш. күңелдән, баштан чыгару, алып ташлау. *Нәфисә уяна гына башлаган бу яңа өметне дә күңеленнән кырып ташлады.* Г. Бәширов.

КЫРУ II *ф.* 1. Күпләп үтерү, юк итү; бетерү. [*Григорьян:*] *Барлык дошманнарны кырып бетермичә, безгә ял юк.* Г. Әпсәләмов. *Мужик, ничектер, Төлкегә очрап, бу Төлке мужикның тавыкларын бик кырганлыктан йөдәгәнгә күрә, бу рәвешчә төлкене вәгазьләргә тотынды.* Г. Тукай. || Ату, атып үтерү. *Немец самолетлары шәһәрдән качып котылырга тырышкан бу бичараларны пулеметтан кырып йөргән икән.* Ә. Еники.

2. Бәреп ватту, ватып кисәкләргә әйләндерү. *Шулай итеп [Мәймүн] Күзлекләрнең барын кырды.* М. Гафури. *Өстәлдәге посудаларны, бутылкаларны кырган вакытта бер пыяла кисәге, атылып китеп, Батыргали агайның күз-кашын ярып җибәргән.* Ш. Мөхәммәдев. || Җимерү; юкка чыгару, бетерү. *Чалгы бер селтәүдә дөньяны кырып төшерердәй бер гайрәт белән ала иде.* Г. Ибраһимов. *Бу көйдә бөтен нәрсәне кырып, җимереп барган ташуларның гөрләве --- ишетелә иде.* А. Шамов.

3. *күч.* Бозу, начарландыру (кәефне). *Егетнең бу зары Хәйдәрнең бөтенләй кәефен кырды.* Г. Бәширов. *Таш йөрәкләр кырсалар күңелеңне, түз, эндәшмә син.* Г. Тукай.

4. *күч.* Нинди дә булса бер эш башкару, эш эшләү. [*Галиулла:*] *Әллә син анда аларны эш кырганнар дип беләсеңме?* И. Гази. || Берәр эш башкарып нинди дә булса нәтиҗәгә ирешү. [*Гыйльмениса җиңги:*] *Буең күсәк кадәр булганчы укып йөрдең, нәрсә кырдың инде.* М. Гали.

КЫРУЛЫ *с.* Пәке белән кырылган, кырып алынган (сакал-мыек турында). *Беренче татар — урта буйлы, сирәк сакаллы һәм мыеклы. Авыз тирәсе кырулы.* Г. Коләхметов.

КЫРЧЫ *и. сөйл.* Кырчылыкта эшләүче; кырчылык белгече. *Юлчы — юлда, кырчы — кырда.* Әйтем. *Җырлар җырлап, җиң сызганып, Эшләп йөри кырчылар.* Н. Исәнбәт.

КЫРЧЫЛ *и. бот.* Кыяклылар семьялыгыннан себеркәч чәчәкле азык үләне; *русчасы:* полевица. *Ак кырчыл.*

КЫРЧЫЛЫК *и.* Бөртекле, техник һәм терлек азыгы культураларын игү эше, шул культураларны игү белән шөгыльләнгән авыл хуҗалыгы тармагы. [*Гашыйк абзый Нургалигә:*] *Син --- азык кытлыгыннан чыгасың килсә, кырчылык бригадаларына салынып торма, үзең башлап артыннан йөр.* Ә. Еники.

КЫРЧЫН *и.* 1. Терлекләрдә була торган корчаңгы авыруының бер төре. || Шул авыру эләккән хайван. || *күч. тирг.* Юньсез. [*Мөхәммәтҗан бабай сыерларга:*] *Әй сез, кырчыннар! Нәрсә җитми тагын сезгә, әллә маегызга чыдаша алмыйсызмы?* М. Гали.

2. *диал.* Чәч астындагы тиредә эренле кутыр барлыкка килә торган йогышлы авыру. || Шул авыру эләккән кеше. *Корчаңгыны кырчын күралмый.* Әйтем.

Кырчын тал(ы) *бот.* — талның бер төре: чыбыклары нәфис һәм нечкә тал. **Кырчын тимрәү** *мед.* — тиредә була торган йогышлы гөмбәчек авыруы.

◇ **Кырчын таз** *тирг.* — юньсез кеше, яман кеше.

КЫРЧЫНЛАУ *ф. сөйл.* Кырчын авыруы белән авыру.

КЫРШАУ I *и.* 1. Такталарын беркетү өчен мичкәгә, кисмәккә һ. б. ш. кидерү өчен бөгеп ясалган металл яки агач түгәрәк, пута. *Тимер кыршау. Агач кыршау.* □ *Кыршаусыз мичкә булмас.* Мәкаль. *Газинур ишекне ачканда, Гөлләр җиз кыршаулы гөбедә тырышып-тырышып май яза иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Металл пластинкадан яки тимер чыбыктан бөгеп ясалган бөжра, түгәрәк. *Стенада нәзек кенә тимер кыршаулар асылынып тора, ә аларга әллә нихәтле ачкычлар, бөжралар, йозаклар, тагын әллә нәрсәләр кидерелгән.* Ә. Фәйзи.

3. *күч. махс.* Түгәрәкләп камап, чолгап алу турында. *Кисеп менеп зәңгәр биеклекне, Ыргылдылар өстән дошманга: Туздырдылар аның кара сафын Һәм алдылар утлы кыршауга.* Ш. Маннур. *Немецлар, кыршау эченә керәбез, ахры, дип уйладылар булса кирәк.* Ә. Айдар.

Кыршау сугу — *к.* кыршаулау. [*Ярулла:*] *Менә бит, төбен кыскач, кыршавын суккач, шап-шактый кисмәк булды.* Ф. Бурнаш. **Кыршау ату** — 1) мичкәнең яки кисмәкнең кыршавы төшү, кыршавы чыгу. [*Берсе:*] *Мичкәң кыршау аткан, юл буенча суы агып килә, ник аны карамадың дип, бабайга тагы берне сугып җибәрде.* М. Гали; 2) *күч. иск.* бөлү аркасында бурычны түли алмас хәлгә килү, банкрот булу. *„Дхмәтсафа агай кыршау аткан", „Дхмеров шартлаган", — дип сөйли башлаганнар иде.* Ш. Мөхәммәдев.

КЫРШАУ II *ф. сөйл.* 1. *к.* кыршаулау.

2. *күч. диал.* Уратып алу. [*Умарталык*] *тирә-ягы каеннар белән кыршатылган бик матур аланда иде.* Ак юл.

КЫРШАУЛАУ *ф.* 1. Мичкәгә, кисмәккә яки агач чиләккә кыршау сугу, аларның такталарын кыршау белән тоттыру, ныгыту. *Кисмәк кыршаулау.* □ [*Карама агачы:*] *Миннән чана табаннары, дугалар бөгәләр, көянтәләр ясыйлар, минем белән мичкәләр кыршаулыйлар.* Г. Галиев.

2. Бөжралау, тирәләү. *Бакыр балдак белән кыршаулаган кечкенә челемен генә күреп калган идем.* Г. Бәширов.

КЫРШАУЛЫ *с.* Кыршауланган, кыршау белән тоттырылган; кысага алынган. *Картның кечерәк борыны өстендә нечкә кыршаулы күзлеге төшәм-төшәм дип кенә атланып тора.* Г. Әпсәләмов. *Кешеләр алтын кыршаулы көзгеләр, диамант алкалар ясыйлар.* А. Тимергалин.

КЫРШАУЛЫК *и.* Кыршауга яраклы яки җитәрлек материал, металл пластинка яки чи таяк, нечкә агач. *Мужик кайткач та бик көйле кыршаулык әзерләп куйды келәттә.* Әкият.

КЫРШАУЧЫ *и.* 1. *сөйл.* Мичкәләрне, кисмәкләрне, агач чиләкләрне һ. б. ш. кыршаулаучы, аларга кыршау сугучы.

2. *иск.* Кыршау белән сәүдә итүче.

КЫРШУ I *ф. сөйл.* Берәр төрле коралны үтмәсләндерү, үтмәс хәлгә китерү. *Пычакны кыршу.*

КЫРШУ II *ф. сөйл.* Нәрсәне дә булса берәр әйбер белән әйләндереп алу; каплау. *Җиде-сигез метр югарылыкта зур тимер шан урнаштырылып, түбән ягы дүрт кырыйлап такта белән кыршыган һәм баштанаяк аксыл-сары буяу белән буялган.* Ш. Камал.

КЫРШЫК *и. диал.* Тискәре, кире кеше, кире беткән кеше.

КЫРШЫЛДЫРУ *ф. сөйл. к.* кыршу I.

КЫРШЫЛУ *ф.* **1.** Даими рәвештә ышкылу сәбәпле кырылу, тузу (күбрәк кием турында). *Ул аны станция базарыннан кыршылып беткән яшел хәрби пиджакка алмаштырып алды.* Г. Гобәй. *Колаклары мескен булып салынып торган кыршылган бүрекле, сырты калкып чыгып торган тар аркалы Миңнур карт, читтән караганда, кызганыч булып күренә иде.* А. Шамов. || Мехның яки тиренең йоны кырылу; ию. [*Майпәрвәз ханым:*] *Кышкы пальтоңның якасы кыршылган түгелме соң?* Э. Еники. *Халиков Солтанның кыршыла төшкән каракүл якалы пальтосына --- күз төшереп алды.* А. Расих.

2. *күч. сөйл.* Ару, хәлсезләнү; йончылу. [*Гайшә:*] *Кыш буе мәктәптә кыршылган кешегә бер-ике ай гына иркендә йөрсә дә ярый.* Ф. Бурнаш. *Бу ике кыршылып искергән, изелеп арган мәхлуклар эчләреннән нәрсә уйлый, тормышның нинди матур күренешләре аларның хыяллары алдында очып йөри икән?* Ш. Камал.

3. *диал.* Үтмәсләнү, үтмәс хәлгә килү (кисү кораллары турында). *Кыршылган чалгы.*

4. *күч.* Нинди дә булса эш башкару, эш башкару өчен көч кую. [*Аю:*] *Үзең бармагач, армагач-талмагач, кыршылмагач, сугышмагач, тик утырып кына койрыклы булып буламы соң.* А. Алиш.

5. *күч.* Нинди дә булса эш белән озак шөгыльләнеп, остарып, шомарып бетү. *Күпне күргән, күп кыршылган Гайфулла, Рәүф янында шулай йомшак ялагайланса, Искәндәр янында ул башка төслерәк сөйли.* Г. Нигъмәти. *Күршем дә кыршылган нәрсә икән, аның тыңламаган булып кылануына игътибар итмичә, үзенең сүзен дәвам итә.* М. Әмир.

6. *кимс. сөйл.* Күзгә күренергә тырышып бер дә юкка йөрү яки басып тору турында. *Кыршылып йөрү.* □ [*Алюк:*] *Юлга хәзерләнмичә, нәрсәгә монда кыршылып торасың.* К. Тинчурин.

КЫРЫГАЛДАР *и. сөйл.* Һәрвакыт алдый торган кеше, алдакчы.

КЫРЫГАР *бүл. саны, сөйл. к.* кырыгышар. *Безнең тачкачылар балыкны бик күп тотып та, кырыгар сум акча эшләү хыялларына инде бит сыптырган иделәр.* Ш. Камал.

КЫРЫГЫНЧЫ *тәрт. саны, к.* кырык. [*Таһир:*] *Кырыгынчы завод коммутаторын бирегез.* Т. Гыйззәт.

КЫРЫГЫШАР *бүл. саны. к.* кырык.

КЫРЫГЫШАРЛАП *рәв.* Кырыгышар итеп.— *Егетләрне вагон саен кырыгышарлап тутырганнар да, капка хәтле ишекне ябып куеп, мимечкә каршы сугышырга озатканнар.* К. Нәҗми.

КЫРЫЙ *и.* **1.** Нинди дә булса бер предметның чите. *Шул вакыт аның күзләре өстәл кырыенда Хәйри онытып калдырган пәкене күрделәр.* Г. Минский. [*Сестра*] *Нуруллин баш астындагы мендәрне уңайлады, одеял кырыйларын кыстырды.* А. Шамов.

2. Берәр урынның (урманның, аланның, торак пунктның һ. б. ш.) тирәсе, аның читендәге җире. *Без авыл кырыендагы яшел чирәм өстендә утырдык.* М. Әмир. *Тау кырыена утырган Ташлыяр авылын менә шул зәңгәр төтен каплаган.* А. Алиш. || Юлның читендә буйдан-буйга сузылган пространство. *Шуннан соң алар юл кырыендагы җәяүлеләр сукмагы белән көнчыгышка киттеләр.* Ә. Еники.

3. Эшләпәнең түгәрәк киң горизонталь чите. *Пальтосы кыршылып беткән, эшләпә кырыйлары шиңгән әрекмән төсле салынып төшкән, авызында арзанлы сигара.* Г. Гобәй. || Кайбер баш киемнәрен уратып алган тар полоса, кырпу. *Киң кырыйлы, кокардалы фуражкалары аларның ак казаклар икәнлеген белдереп тора иде.* Ш. Усманов.

4. Нинди дә булса бер предметның, мәйданның читен чикләүче сызык. *Гали абзый, планга карап, колхоз җиренең кырыйларын күрсәтә дә, Газинурга ат башыннан тотарга куша.* Г. Әпсәләмов. || Елга, күл, диңгез суы белән җир тоташа торган сызык. *Тик көн урталарында сазаннар кырыйга якын килеп, лайлалы балчыкка чумып торалар.* Ш. Камал. || Шул чик янындагы урын, пространство. *Тиз-тиз сикереп төшеп, көймәне кырыйга да тартып чыгардык.* М. Җәлил.

5. Нинди дә булса бер предметның ян өслеге, бер ягы. *Арыш чумәләләре кырыена башыңны куясың да болытларга, болытлар артындагы айга карап үткәннәреңне яки киләчәгеңне уйлыйсың.* Г. Гобәй. || Нинди дә булса бер савытның авыз чите, ирнәве. *Стакан кырые.* □ [*Сәлимә:*] *Вазаларның зәңгәр читлеләрен куйма: аның берсенең бер кырые бераз кителгән, ал читлеләрен куй!* Ф. Әмирхан.

6. *с. мәгъ.* Үзәктән читтә булган, нәрсәнең дә булса читендәге; читтәге. *Кырый бүлмәгә узышлый чаршауны күтәреп, Галимуллинга урын күрсәтте.* К. Нәҗми.

7. *рәв. мәгъ.* **кырыйга.** Нәрсәдән дә булса бер якка, бер читкә. *Мәйданны чыгар алдыннан ат бераз уңгарак борылган иде, халык, үзләре өстенә килүеннән куркып, бер кырыйга йөгерә башлады.* М. Гали.

8. *рәв. мәгъ.* **кырыйда.** Нәрсәдән дә булса бер якта, бер читтә, уртада түгел. *Бер кырыйда тулган ай, урман эчләренә моңсу ак нурын сибеп, әкрен генә йөзә.* Г. Әпсәләмов.

9. *с. мәгъ.* **кырыйдагы.** Берәр үзәктән читтә булган, нәрсәнең дә булса читенә урнашкан. *Урам башыннан кереп кенә җиттеләр, кырыйдагы өйдән, кулын болгый-болгый, шинель кигән бер абый йөгереп чыкты.* Г. Бәширев.

10. *рәв. мәгъ.* **кырыйдан.** 1) нәрсәнең дә булса иң читеннән, үзәктән иң ерак урыннан. *Аннары бер урамга борылып керәсең дә, кырыйдан бер йорт кала.* А. Алиш; 2) бер як читтән, нинди дә булса бер яктан. *Кырыйдан карап тору.*

Кырый чыгыш — балалар уенының бер төре. [*Кыз балалар*], *караңгы төшә башлагач, „кырый чыгыш", „түндек алыш" --- уйнарга тотыналар.* Ш. Әхмәдиев.

◇ **Кырый(га) кагу** — 1) кыерсыту, рәнҗетү. *Татар буржуазиясе моның өчен мине кырыйга гына какты.* Г. Камал; 2) читкә кагу, кабул итмәү. *Әни аның сүзен кырый какты: „Үзең куркасың да малайны җибәрмәкче буласың, үзең бар",— диде.* Г. Толымбай. **Кырыйда калу** — *к.* читтә калу.

КЫРЫЙЛАП *рәв. сөйл. к.* кырыйлатып.

КЫРЫЙЛАТЫП *рәв.* Берәр нәрсәнең кырыеннан, читеннән, эченә кермичә. *Кырыйлатып бару.* □ [*Камали*], *Казанка елгасына чыгып, аннан яр кырыйлатып кына Бишбалтага юнәлде.* К. Нәҗми.

КЫРЫК *сан* **1.** 40 саны. *Кырыкка сигезне кушу. Кырыктан унны алу.* || Шул сан исәбендәге микъдар. *Кырык пот. Кырык гектар. Кырык китап. Кырык ел. Кырык яшь.*

2. Кайбер тезмә сүзләрнең беренче кисәге, кырык өлештән, кырык берәмлектән тора дигән мәгънәне аңлата: *кырык чиләкле, кырык градуслы, кырык еллык.*

3. *күч.* Бик күп. [*Үзе*] *кырык ямаулы бишмәт кисә дә, аның кеше арасында күңеле китек булмасын дип, ел саен диярлек яңадан-яңа күлмәкләр, бишмәтләр, яңадан-яңа шәләләр алып бирергә тырышты.* Г. Ибраһимов. *Сүз сөйләсәң, сару кайный башлый, Алдың-артың кырык борасың.* М. Җәлил.

4. *и. мәгъ.* **кырыгы** *дини.* Кеше үлгәннән соң кырык көн үткәч, аны искә алу йөзеннән үткәрелә торган йола. *Чама белән генә булса да вакытын билгеләп, я кырыгын, я еллыгын уздыралар.* Г. Бәширов.

Кырык катлама — өстенә май, мәк, повидло һ. б. ш. якканнан соң, кат-кат итеп, билгеле бер кисәкләргә турап, мичтә пешерелгән камыр ашы. **Кырык карта** — күшәүче хайваннарның ашказанындагы бер бүлек. *Күшәлгән һәм селәгәй белән мул чылатылган азык ярым сыек ботка хәленә килә. Бу ботка --- ашказанының өченче бүлегенә — кырык картага төшә.* Зоология. **Кырык корама** — 1) бик күп төрле вак чүпрәк кисәкләреннән, кыеклардан тегеп ясалган әйбер (мәсәлән, юрган, палас һ. б); 2) *күч. кимс.* төрле төрдәге әйберләрнең кушылмасы. **Кырык тартма товарлары** *иск.* — галантерея, галантерея товарлары. *Эт тә, мәче дә кызыгырлык нәрсә юк анда, кызыл мал белән кырык тартма товарлары гына.* М. Гали. *Артта көйләп-көйләп товар тәкъдим итүче кырык тартмачылар, нәүрүз әйтеп утыручы сукыр хәерчеләр, сәләмә киемле, ялтыр күзле сукбайлар калды.* А. Расих. **Кырык теш (тырнак)** — тегермәндә су яки җил көчен тегермән ташына тапшыра торган деталь, тешле тәгәрмәч. [*Тегермәннең*] *„кырык тырнагы“ кыза дип, Бәдри Аграфена тутидән бераз май да сорап алды.* И. Гази. **Кырык чөй** *диал.* — *к.* кырык теш. *Җизни мине тегермәннең астына алып төшә, кырык чөйләрне күрсәтә.* Ф. Хөсни.

◊ **Кырыгына бер иман** — барысы да ышанычсыз, ышанычлы түгел. [*Шәмсетдин:*] *Андыйлар бит тегендә дә сатылалар. Андыйларның бит аның кырыгына бер иман.* Г. Бәширов. **Кырык (бер) кат, кырык (бер) мәртәбә** — бик күп мәртәбә, бик күп кат. *Кырык кат сөйләү.* □ [*Йосыф:*] *Ләкин бу сөйләгән сүзләреңә һәммәсе безнең кырык бер мәртәбә ишеткән сүзләребез булып чыктылар.* Ф. Әмирхан. **Кырык даланың кырыена** — кешеләр яши торган урыннан бик ерак, ерак җиргә. [*Сафия:*] *Ышанмаган булсам, синең белән бер ялгызым кырык даланың кырыена килмәгән булыр идем.* Ш. Камал. **Кырыкка бер тулмаган** *гади с.* — юләр, ахмак кеше турында. **Кырыкка бөгү** — ихтыярсыз, көчсез кеше белән ничек теләсәң, шулай эш итү, аны теләсә нинди эшкә күндерү. **Кырыкка телгәләнеп беткән** — 1) тузган, сәләмәләнеп беткән; 2) хәлсезләнгән. *Кырыкка телгәләнеп беткән йөрәк.* **Кырыкка ярылу** — эш бик тыгыз һәм күп булганда, берьюлы берничә эшне башкарырга яки берничә урында булырга кирәклекне белдерү өчен кулланыла.— *Д үзе, бер кеше кырыкка ярылырдай кызу эш вакытында, колхоздан тегесен-монысын даулый.* Г. Әпсәләмов. **Кырыктан артык кыңгыр як** — бик күп җитешсезлекләр, кимчелекләр турында. **Кырык фарыз** *дини* — мөселман кешегә белү һәм башкару мәҗбүри булган кырык төрле вазифа. *Коллык күрсәтү кебек эшләр --- иман шартларындагы кырык фарызларны ятлаудан да, намаз вакытында ягъзаларны туры тотудан да авыр булды.* М. Гафури. **Кырык чөйләре кырылып бетсен, кырык чөе кырылып китмәгәе** — теләсә нәрсә булсын, теләсә нинди хәлгә килсен. [*Биби:*] *Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда.* Г. Камал. *Кырык чөең кырылып китмәгәе дип карап, үзләренә печән хәзерләп йөрүчеләр --- уңдылар.* Р. Төхфәтуллин. **Кырык эш кырылып яту, кырык эш кырык җирдә яту** — эшнең бик күп булуын, эшнең бик тыгыз булуын белдерә. [*Фатыйма:*] *Кырык эшем кырылып ятканда, бусы кайтып, эш ясап китте тагын.* И. Гази. **Кырык ясин чыгу** *дини* — коръәннең „ясин“ дип аталган сүрәсен кырык мәртәбә уку (дингә ышанучыларның карашы буенча шул вакытта, янәсе, үз теләгенә ирешеп була). *Насыйр мәхдүм, өч хәтем корьән, кырык ясин чыгып* [*солдаттан*] *калдым, дип әйтә, ди.* Г. Ибраһимов.

КЫРЫК-ИЛЛЕ *чама саны.* Кырык белән илле тирәсендә; иллегә якын, илле чамасында.— *Икенче шушындый агачның үсүен кырык-илле ел көтәргә кирәк.* Г. Әпсәләмов. *Конторщиклар, капка төбендә торучы сакчыга кырык-илле тиен чәйлек төртеп, төндә йөреп-йөреп кайталар.* Ш. Мөхәммәдев.

КЫРЫКЛАП *чама саны. к.* кырык. *Ишектән керү белән дивар буйлап кырыклап казак тезелеп киткән.* Г. Ибраһимов.

КЫРЫКЛЫ *с. сөйл.* **1.** Кырыгынчы үлчәүле, кырыгынчы размердагы. *Кырыклы итек. Кырыклы ботинка.*

2. *и. мәгъ. гади с.* Кырык градуслы аракы. [*Җәүһәрия:*] *Кыз башым белән кырыклы ташып йөрисем юк.* Р. Ишморат.

КЫРЫКЛЫК *и. иск.* Чиләкнең $^1/_{40}$ өлеше сыешлы шешә.

КЫРЫКМА *с.* Билгеле бер рәвешкә китереп кырылган. [*Рәшит*] *начальникның агарып әчкә кергән яңакларына, кырыкма мыеклы иреннәренә карады.* Л. Гыйльми.

КЫРЫКМАСА: кырыкмаса кырык — бик күп тапкыр, исәпсез-хисапсыз. *Мин кырыкмаса кырык тапкыр әйттем.* А. Әхмәт. [*Каюм*] *килгәндә, күрәсең, кырыкмаса кырык егылгандыр.* Г. Гобәй.

КЫРЫКМЫШ *и.* Бер яшь тулып, икенче яшькә чыккан һәм, гадәттә, ялы, койрыгы кыркылган тай. *Болын буйларын яңгыратып, колыннар, кырыкмышлар кешнәп җибәрә.* Г. Бәширов.

Кырыкмыш суган — вак кыяклы суган. **Кырыкмыш тай** — *к.* кырыкмыш. *Безнең әти узган ел көз --- икенче яшькә чыгып кына калган кырыкмыш тай алып калдырган иде.* М. Гали.

КЫРЫКТАРТМАЧЫ *и. иск.* Элекке вакытта: авылдан авылга йөреп, күбрәк галантерея белән сату итүче вак сәүдәгәр. *Д ул менә Сөяк илтеп кырыктартмачыга, днисенә дару алмакчы.* Х. Туфан.

КЫРЫЛУ I *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* кыру I. *Әйбере дә аз, күбрәге камыт, ияр, өем-өем киезләр белән дөядән, куйдан кырылган йоннар, атлардан алынган төен-төен кыллар иде.* Г. Ибраһимов.

2. *диал.* Ышкыла-ышкыла яки озак киюдән тузу, өске өлеше зарарлану (кием һ. б. ш. турында). *Былтыргы бишмәт тузган, былтыргы пима тишелгән, оекларның табаны кырылган инде.* М. Гафури.

КЫРЫЛУ II *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* кыру II (1, 2, 3 мәгъ.).

2. Күпләп үлү (кешеләр турында). *Төрле авырулардан кырылалар шул кешеләр ки, кайсылары кан тирләргә батып эшлиләр — хезмәт итәләр.* Г. Тукай. *Ялачич боярының ундүрт мең десятинә җире булган, ә халык җирсезлектән тилмергән, ачлыктан кырылган.* Г. Әпсәләмов. || Терлекләрнең күпләп үлүе, аларга үләт төшү. *Терлек кырылу.*

3. Ватылу, чәлпәрәмә килү. *Аның тәрәзә пыяла-лары болай кырылмаган, аның кәрнизләре, почмаклары болай ишелмәгән, җимерелгәләп бетмәгән иде.* Ф. Әмирхан. || Җимерелү, таркалу. *Я ашыклар кырылу тавышы урынына үз аткыңның җир өстенә дөп итеп килеп сугылу тавышыннан тыш берни ишетелми.* Ә. Фәйзи. *Ярдәмгә безнең танклар Килеп җиткәндә*

инде, немецларның танклары Кырылып беткәннәр иде. Ә. Исхак. || *күч.* Юкка чыгу, җимерелү. *Шул өметләр атлаган саен кырыла бара.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Бозылу, начарлану, китү (күңел, кәеф). *Менә шуннан соң аның кәефе тәмам кырылды.* А. Шамов.

5. *күч. сөйл.* Хәлсезләнү; сәламәтлек какшау. *Эшләп кырылу.*

КЫРЫЛЫШ *и.* Күп корбаннар таләп итә торган сугыш. *Аның белән җирдә соңгы сугыш, соңгы кырылыш, Соңгы кан булыр.* Һ. Такташ.

КЫРЫМСАГЫЗ *и. махс.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан каучук бирә торган күпьеллык үсемлек; *русчасы:* крым-сагыз. *Соңгы елларда Советлар Союзында кыргый флорада кыйммәтле үсемлекләр табылды. Каучук бирә торган тау-сагыз, кырымсагыз, күксагыз үсемлекләре ачылды.* Робинзон эзл.

КЫРЫН *рәв.* 1. Горизонталь яссылыкка беркадәр авышлык ясап, янтайган рәвештә. *Солтан җитез генә кашын төзәтте, пилоткасын бераз кырынрак салды.* Г. Бәширов. *Сары самовар, чәйнеген кырын салып, күңелле сызгырып, буш табында ялгыз гына утыра.* И. Гази.

2. Кемгә яки нәрсәгә дә булса ян белән, бер як белән. *Рәхилә исә, кыймылдарга куркып, анасына кырын басып тора.* Ә. Ерикәй. [*Нургали Сөләйманов*] *яныннан кырын узып тышка чыкты.* Ә. Еники. || Туры карамыйча; йөзне икенче бер якка табан тотып, күзне берәр кешегә яки нәрсәгә юнәлтеп. *Җиһанша җизни, Мәликә җиңгигә кырын карап, нидер усал бернәрсә әйтергә теләсә дә, сүзен әйтми чәен эчеп җибәрде.* Һ. Такташ.

3. *с. мәгъ. күч.* Ялгыш, гадел булмаган; начар. *Туры утырып кырын уйлаганчы, кырын утырып туры уйла.* Мәкаль. *Кырын эш кырык елдан соң да беленә.* **Әйтем.** *Башлаучы юл башлыгы булмаганда, Бик җиңел кырын юлга барып керү.* М. Гафури.

4. *бәйл. мәгъ.* Таба. *Кичкә кырын апам килеп җитте.* А. Шамов. *Бәйрәм көн кичкә кырын клубка халык җыелды.* М. Гали. **Кырын килү** — 1) кырынаю, янтаю. *Арбаң аз гына кырын килсә, чана кебек тиз-тиз итеп, тау асты ягына таба китә башлый.* Г. Ибраһимов; 2) *күч.* каршы килү, уңай булмау, авырлыклар килеп чыгу. *Дөнья Зәйнәпкә гел кырын килеп, бер дә ачык йөз күрсәтмәгәч, аның күңеле кайда булса да разый булырга гына тора иде.* М. Гафури. *Кырын килсә килер икән кешегә, --- берсе дә ул дигәнчә булып чыкмады.* Ф. Хөсни.

◊ **Кырын (күз белән) карау** — 1) туры карамау; 2) *күч.* начар дип карау, яратмау, үз итмәү. *Мин мәдрәсәне ташлап чыккач, власть кешеләре миңа бик шикләнеп, кырын карадылар.* К. Нәҗми. [*Сәрбиҗамал:*] *Һәммәсе кырын күз белән карыйлар.* Г. Камал. **Кырын күзләп карау**—*к.* кырын (күз белән) карау 1). *Фәрихә, көлемсерәгән хәлдә, кырын күзләп кенә Мостафага карый.* Ш. Камал. **Кырын күз(не) салу (ташлау)** — *к.* кырын (күз белән) карау 1). *Күрми һәм хәзрәт бу картны, тик кырын күзен сала.* Г. Тукай. [*Гөлбану*] *Сания белән Гөлзадәгә кырын күз ташлап кызу гына чыгып китә.* Р. Ишморат. **Кырын тору** — 1) яхшы мөнәсәбәт, мөгамәлә күрсәтмәү; сөйләшергә теләмәү. *Председатель Нургалинең кырын торуын ачык күрсә дә, аны-моны уйламыйча, сүз башлар өчен: „Тимерчеләр янында булган идем әле",— диде.* Ә. Еники; 2) гел каршы булу, киртә-кыенлыклар чыгып тору.

КЫРЫНАЙТУ *ф.* Бер якка авыштыру, янтайту (арбаны, көймәне һ. б.). *Көймәне кырынайту.*

КЫРЫНАЮ *ф.* Бер якка авышлану, авыш хәлгә килү, янтаю. *Арба кырынайды.* □ *Сәхип оялды, башы белән бер якка кырынаеп, җиң очын авызына капты да тик торды.* Г. Ибраһимов.

КЫРЫНГЫЧ *и. сөйл.* Кырыну әсбабы, кырыну приборы.

КЫРЫНДЫК *и.* 1. Нинди дә булса савыт төбеннән кырып-сибереп алган калдык.

2. *диал.* Күәс төбеннән кырып алынган камырдан пешерелгән кечкенә ипи; шишара.

КЫРЫНЛАП *рәв.* Ян белән, кырый белән. *Атлар кырынлап чаптылар-чаптылар да, Митричевны санламыйча, шул кое янына килеп туктадылар.* Г. Бәширов.

КЫРЫН-КЫРЫН *рәв. сөйл.* 1. Туры карамыйча, йөзне бер якка, күзне икенче якка юнәлтеп. *Бу караңгы чырайлы кеше янында Сөләймановның үзенең дә күңеле боега башлады, һәм ул Коненкога кырын-кырын карап алды.* И. Гази.

2. Бер ян белән, бер як белән. *Рокыя, шәленә капланып, кырын-кырын чыгып китә.* Ф. Әмирхан. || Кача-поса. *Бүтәннәре кырын-кырын капка артына яшеределәр.* Г. Бәширов.

КЫРЫН-МЫРЫН *рәв. сөйл.* Килешми, ышанмый; каршы. *Ул тыңлар-тыңламас, кырын-мырын утырган шәкертләрнең үзенә ышанмыйча көлеп караган күз карашлары астында [сабакны] дәвам итте.* Ә. Фәйзи.

КЫРЫНТЫ(К) *и.* Кисәк-кисәк, вак кисәкләр (күн һ. б. ш. әйберләрнең калдыклары турында). || *с. мәгъ.* Кисәк-косактан, вак кисәкләрдән торган. *Кырынтык күннәр ябыштыру промыселы.*

КЫРЫНУ *ф.* Пәке белән сакал-мыекны төбенә кадәр кисү, кистерү; кисеп алу, кистереп алу. *Аштан соң егетләр кырынырга, чистарынырга тотындылар.* А. Шамов.

КЫРЫН-ЯРЫН *рәв. к.* кырын-мырын.

КЫРЫП-БЕТЕРЕП *рәв.* Бөтенләй юк итеп, тулысынча юкка чыгарып. *Шушы икән "инде ул бәйдән ычкындырып җибәрелгән өер! Ватып-җимереп, яндырып-көйдереп, кырып-бетереп килүче „батырлар".* Ә. Еники.

КЫРЫП-СЕБЕРЕП *рәв.* Барысын да, бер дә калдырмыйча. *Кырып-сибереп алу. Кырып-сибереп бирү.*

◊ **Кырып-сибереп ташлау** — юкка чыгару, юк итү. *„Черек стройны кырып-сибереп ташлаячак революция давылының якынлашуы" турында борчулы сүзләр ишеткәләгәч, ул үзенең барлык эшләренә күл селтәде дә тизрәк Казанга ашыкты.* К. Нәҗми.

КЫРЫС *с.* 1. Каты табигатьле, усал, йомшак мөгамәлә күрсәтми торган. *Элек-электән кырыс Зөһрә, әтисе үлгәч, бөтенләй чыгырыннан чыкты.* Ә. Фәйзи. [*Мәрьям:*] *Әти-әниләр бик кырыс булдылар, мәрхүмнәр.* Ш. Камал. || Каты, йомшак түгел (күңел һ. б. турында). *Кырыс күңелле кеше.*

2. Каты күңеллелекне белдереп торган; артык җитдилек чагылып торган. *Кырыс караш.* □ [*Мурин*] *шундук, үтә кырыс тонга күчеп, ялгап алып китте.* Ф. Хөсни. *Тормышның бөтен авырлыгын үз җилкәләрендә күтәргән бу кырыс чырайлы апаларның шулай тирән кайгыга батулары малайны каушатып җибәрде.* Г. Бәширов. || *рәв. мәгъ.* Артык кискен, җитди, катгый. *Анда аларның кырыс-кырыс кына сөйләшкәннәре, аннары ниндидер авыр нәрсәне идәннән шудырып урынныннан кузгатканнары, йозак-келә шылтыравы ишетелеп торды.* Р. Төхфәтуллин. *Якуб абзыйның кара тутлы какча йөзе беренче карашка шактый кырыс күренә.* М. Хәсәнов.

3. Кыргый, кулга ияләшмәгән яки ияләшеп җитмәгән; усал. *Кырыс айгыр, артык көч белән тартылып, көтүчене ярым екканда, ләкин аякларын иярдән,*

өзәңгедән чыгарып җиргә төшерә алмаган иде. Г. Ибраһимов.

4. Тормыш алып бару өчен кыен, яшәү өчен авыр, уңайсыз. [*Мансур:*] *Себернең кырыс табигате җиңел генә баш иясе килми безгә. Юлларыбызны кар күмеп китә.* Р. Ишморат.

КЫРЫСЛАНУ *ф.* 1. Артык җитдиләну, артык җитдигә әйләну; беркадәр рәхимсезләну. *Моңарчы да күп кайгыларны, сынауларны баштан кичерә килгән Мостафаның йөзе кинәт кырысланды.* К. Нәҗми. *Тәр якта әнкәсе --- утыра, аның күзләре, ягымлылыгын җуеп, кырысланган, битендәге җыерчыклары тагын да тирәнәйгән.* Г. Бәширов.

2. Салкынаю, уңайсызга әйләну (һава, климат турында). *Кырысланды һава, Көн-төн яңгыр ява.* Ә. Юныс.

КЫРЫСЛЫК *и.* 1. Каты күңеллелек, каты табигатьлелек. [*Хәйдәр:*] *Кырыслык үземдә дә бераз бар минем.* Р. Ишморат. || Артык җитдилек, кискенлек. *Бөтенесендә сугышның авырлыгын, хәлләрнең җитдилеген искәртеп, үзенә күрә бер кырыслык бәреп тора иде.* Г. Бәширов. *Кәбиргә Кондаковның кырыслыгы һәм болай турыдан-туры егетне озатырга җыенуы ошап җитмәде.* А. Гыйләҗев.

2. Кыргый булу, кырыс булу; кулга ияләшмәгән булу. *Ала айгырның куркуы катыш кырыслыгы* [*җылкычыдан*] *бик күп көчле иде.* Г. Ибраһимов.

3. Тормыш өчен авыр булу, яшәү өчен кыен булу. *Табигатьнең кырыслыгы.*

КЫРЫШТЫРУ *ф. сөйл.* 1. Бер җирне дә калдырмыйча йөрү, йөреп чыгу. *Ул, бүген көне буе шәһәрнең бөтен урамнарын кырыштырып, үзенә бүлмә эзләп йөргән.* Ф. Әмирхан.

2. *диал.* Җимерү, вату. *Әйберләрне кырыштыру.*

КЫСА I *и* 1. Нәрсәнең дә булса кырыйларын беркетеп, ныгытып куя торган рамка. *Иләгенә күрә кысасы.* Әйтем. *Пластинкалар таралып китмәсен өчен, алар калайдан ясалган махсус кыса ярдәмендә кыстырып куелалар.* Радио сөюче... || Күзлек пыяласын беркетеп куя торган рамка. *Мулла шүрлектәге китаплары өстеннән бер пыяласы ватылган тимер кысалы күзлеген алды.* А. Шамов.

2. Рам, тәрәзә рамы. *Ләкин тәрәзә кысалары арасыннан туктаусыз ыжгырып торган кызганычсыз җилнең көйләве --- Искәндәрнең --- планын җимереп ташлый.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

3. *махс.* Машина, җайланма утыртылган терәк, рама. *Аңа --- коры кысасы гына калган автомашина беркеттеләр.* Соц. Тат.

4. *күч.* Нәрсәнең дә булса чиге, шартлы кагыйдәсе. *Логика кысасы шундый иде. Салкын акылның хәйләкәр комбинацияләре Заһидның һәрбер эшен аклый иде.* А. Расих.

Кысага утырту — нәрсәне дә булса кысага беркетү, нәрсәгә дә булса кыса кую. *Йөзек кашын кысага утырту.*

◇ **Кысадан чыгу** — берәр нәрсәнең чигеннән, билгеләнгән кагыйдәләрдән читкә чыгу. **Кысасына сыймау** — берәр нәрсәгә туры килмәү, билгеләнгән чикләргә туры килмәү.

КЫСА II *и.* Хатын-кызлар күлмәгенең билдән югары өлеше. *Кызларның күлмәкләре киң вә озынлыкта уртача булып, фәкать бер кыса вә ике катлы зур-зур итәкләрдән генә* [*кушылып ясалган*] *буладыр.* З. Бәшири.

КЫСАН *с.* 1. Пространствосы, мәйданы бик кечкенә, тар булган; урыны бик аз булган (бина, бүлмә һ. б. турында). *Иркен, якты һәм бай залда үткәргән шатлыклы сәгатьләрдән соң, үзеңнең кысан, күңелсез һәм ипсез бүлмәңә кайткач, бу ияләшкән торагың ошамый башлый.* Р. Төхфәтуллин. *Серебряковның кысан каютасында алар бик озак сөйләшеп утырдылар.* И. Гази.

2. Гәүдәне, аякны кыса торган, тар (кием турында). *Кысан кием.* □ *Аяк киемең кысан булса, дөньяның иркенлегеннән ни файда.* Әйтем.

3. *күч. сөйл.* Авыр, читен, кыен, начар (ашау-эчү һ. б. ш. турында). *Ләкин өйдә ашау-эчү ягы бик кысан, ипи-күмәч сирәк була, күбесенчә иртә-кич бер буш аш белән калалар.* Г. Гобәй.

КЫСАНАЮ *ф. сөйл.* 1. (Бинаның, бүлмәнең һ. б. ш.) файдалана торган мәйданы азаю, урыны тараю. *Бүлмә кысанайды.*

2. *күч.* Начарлану, авырлашу (тормыш һ. б. ш. турында). *Тормыш кысанаю.*

КЫСАНЛАНУ *ф. сөйл. к.* кысанаю.

КЫСАНЛАШУ *ф. сөйл. к.* кысанлану.

КЫСАНЛЫК *и.* 1. Кысан булу, кысан булу хәле, (бинаның, бүлмәнең һ. б. ш.) мәйданы аз булу, урыны тар булу. *Бүлмәнең кысанлыгы.*

2. *күч.* Ирексезлек, хокуксызлык. *Капитал коллыгы кайтып, Кысанлык җилләре исте.* Г. Камал. || Авырлык; бернәрсә дә эшләргә мөмкин булмау. *Бүген* [*Зыя*] *эчендә яшәгән тормышның артык тарлыгын, артык кысанлыгын, аның тончыгып үләрлек мәртәбәдә сасылыгын бигрәк ачык тойды.* Г. Ибраһимов.

КЫСКА *с.* 1. Озын булмаган, озын түгел, озынлыгы зур булмаган; *киресе:* озын. *Кыска юл. Кыска таяк.* □ *Мөхәммәтҗан бабай безнең икебезгә дә очына кыл ялгап, бик каты шартлый торган кыска саплы озын чыбыркы ишеп бирде.* М. Гали. || Озынлыгы ягыннан кирәк булганнан кимрәк, азрак. *Күлмәк кыска булган.* || Тәбәнәк, буе озын булмаган (кеше турында). *Кыска буйлы, киң җилкәле Гата үз киңәшен әйтте.* К. Нәҗми.

2. Дәвамлы булмаган, озакка сузылмаган (вакыт турында); *киресе:* озак. *Кыска көн.* □ *Шул кыска гына вакыт эчендә* [*мөгаллим*] *бу авылга тәмам ияләшә.* Ш. Камал. || Озак дәвам итми торган; бик тиз үткәрелә (башкарыла) торган (эш-хәрәкәт һ. б. турында). [*Анисимов:*] *Без бүген сменадан соң кыска гына җыелыш үткәрергә булдык.* Р. Ишморат. [*Паровоз*] *кыска бер гудок биреп кенә узып китте.* Ш. Усманов. || Тиз темпта башкарыла торган (җыр, көй турында). *Равил бер кыска көй уйный, Зәйтүнә җырлый.* А. Әхмәт. *Сәхнә артында егетләр-кызлар кыска көйгә җырлыйлар.* М. Фәйзи.

3. Үзенең эчтәлеге, күләме белән озын булмаган, озынга сузылмаган (сүз, сөйләү, хат һ. б. турында). *Кыска җөмлә. Кыска җавап.* □ *Мин кыска әсәрләр язып, көннең кадагына сугарга тели идем.* Г. Камал. || *рәв. мәгъ.* Озынга сузмыйча, артык киңәйтмичә. [*Бикмашев:*] *Бик кыска гына сөйләшеп алабыз.* Ш. Камал.

Кыска булу — 1) озак дәвам итмәү, тиз бетү. *Ләкин бу шатлык бик кыска булып чыкты.* Г. Гобәй; 2) аз сүзләр белән катгый фикер белдерү (әйтү). *Миңнулланың җавабы бик кыска булды: „Кемгә чыкса, шунысы булыр".* М. Гали. *Килер ул көн, халык хөкем итәр, карар булыр кискен һәм кыска.* М. Җәлил. **Кыска вакытлы** — озак дәвам итмәгән, дәвамлы булмаган. [*Фәтхи*] *җәй көне, кыска вакытлы отпускасында, әткәсе белән әнкәсенең киңәшләре буенча, авылга Ишмай абыйсына кунакка килде.* Ш. Камал. **Кыска иҗек** *шигъ.* — антик шигырь төзелешенә хас иҗек, аның әйтелешенә бер мора вакыт китә. *Антик шигырь төзелешендәге шигырь үлчәменең нигезендә кыска һәм озын иҗекләр ята.* Н. Гыйззәтуллин. **Кыска кием** *иск. этн.* — ирләр өчен милли

кием саналган озын бишмәткә һәм җиләнгә капмакаршы буларак 20 йөз башында керә башлаган костюм, пиджак, кыска пальто кебек өс киемнәре турында. *Хәлил Галиев --- мыегын һич үстерми, сакалын һич кырмый, кыска кием кими, боларны эшләгән кешеләрне сөймәс, хәтта, мөмкин булса, сүкмичә дә калмый.* Ф. Әмирхан. **Кыска (көпшәле) мылтык** — көпшәнең бер өлеше кисеп алынган мылтык. *Шомлы көзге караңгы төннәрнең берсендә кыска көпшәле мылтык тоткан бер явыз аңа һөҗүм дә итте.* А. Әхмәт. *Арбалар тирәсендә винтовкалар, балталар, кыска мылтыклар айкала башлады.* Г. Бәширов. **Кыска пальто** — киемнең бер төре буларак, тездән югары итеп тегелгән пальто. **Кыска сроклы** — аз вакыт эчендә үтә яки үткәрелә торган, озак дәвам итмәгән; аз сроклы; аз срокка билгеләнгән. *Кыска сроклы ссуда. Кыска сроклы курслар.* □ *Бу эш махсус программа белән, либреттистлар өчен кыска сроклы курс-семинар үткәрү, музыка белгечләренең системалы лекцияләрен оештыру төсендә була.* М. Җәлил. **Кыска сузык** — яңгырашы (әйтелеше) микъдар ягыннан озын булмаган сузык. *Озын һәм кыска сузыклар.* **Кыска тун** — озынлыгы тездән югары итеп, гадәттә сарык тиресеннән тегелгән кыска өс киеме. *Тимергали агай ферма сарыкларыннан алган йоннан ун пар киез итек бастырып, берничә кыска тун тектерде.* Г. Бәширов. *Участокта өстенә кыска тун, башына кеш мехыннан тегелгән бүрек кигән партоешма секретаре Павел Иванович Иванов күренде.* Г. Әпсәләмов. **Кыска чәчле** — чәче кистерелгән, чәче кыска калдырылып һәм билгеле бер рәвеш бирелеп кистерелгән (хатын-кызлар турында). *Кыска чәчле хатын, борылып, эчке бүлмәгә кычкырды.* Г. Ибраһимов. **Кыска ялганыш** *физ.*— гадәттә электр җайланмасында авария китереп чыгара торган, электр чылбырындагы дөрес булмаган ялганыш. *Көчәнеш зур булганда, кыска ялганыш тогы бик зур булуы мөмкин.* Физика.

◇ **Кыска (г)акыллы** — *к.* акылы кыска. [*Фәхрелбәнат:*] *Сезнең күргән төшләрегезгә безнең кеби кыска гакыллы адәмнәрнең гакылы җитешә алмыйдыр.* З. Һади. **Кыска аяк** *гади с. кимс.*— хатын-кызга карата кимсетеп әйтү сүзе.— [*Нокта Вәли*] *бер кыска аякка килеп әлгә дә, кулында менә дигән тимер корал булган хәлдә, һичнәрсә эшләтә алмый!* Ш. Камал. **Кыска гына (итеп) әйткәндә** — аз сүзләр белән әйткәндә; җыеп әйткәндә. *Бу күренешләр, кыска гына әйткәндә, мәгъдән заводы турында безгә дә ачык тасаувыр бирә алмыйлар.* Г. Нигъмәти. **Кыска гомерле** — озак вакыт дәвам итмәгән яки дәвам итә алмый торган. *Әмма бу куаныч кыска гомерле булып чыкты.* Г. Бәширов. **Кыска койрык** *гади с. кимс.*— үзен берничек тә жаваплы санамаган принципсыз кеше. [*Тиреченге Гайнетдин:*] *монда җыен кыска койрыклар эшне үз кулларына алганнар, әмма зур хәзрәтләр артта кысылып утыралар.* Г. Ибраһимов. **Кыскасын (гына) әйткәндә** — *к.* кыска гына әйткәндә. *Кыскасын гына әйткәндә, бөтенләй чеп-чи наданнар, шулай була торып та сүзләрен үз әмерләре белән йөртергә тырышалар.* Г. Камал. **Кыска сүзле** — үзенең фикерләрен аз сүзләр белән белдерүче, күп сөйләргә яратмаучы. *Кыска сүзле, чая күзле, Аңарда көч җилкенә.* Ф. Кәрим. **Кыска тоту** — 1) сүзне (сөйләүне) озакка сузмау, сүзне тиз бетерү. *Сүзне бик кыска тотарга туры килде.* И. Гази. *Сүзне кыскарак тот, минем барасы җир бар.* Ш. Камал; 2) бик кискен эш итү. — *Болай калса, эшне кыска тотмый хәл юк.* М. Фәйзи. **Кыска тәртә** *ирон.*— холыксыз кеше, тар күңелле кеше.

КЫСКАЛЫК *и.* 1. Озын булмау, кыска булу. *Алдыгызга китерегез. хәзерге шәкертнең ачлыгын, үз җәһаләтен төшенүен, чәченең кыскалыгын, үзенең чыра шикелле ябыклыгын.* Ф. Әмирхан.

2. Дәвамлы булмау, бик аз булу (вакыт турында). *Вакытның кыскалыгы.*

3. *күч.* Теге яки бу фикерне аңлатканда, нинди дә булса вакыйга турында сөйләгәндә бик аз сүзләр кулланылу. *Кыскалыкта — осталык.* Мәкаль. [*Гарифҗ*] *арыган кыяфәттәрәк, бер терсәгенә белән өстәлгә таянып, яртайган килеш утырган, кыскалык белән өзеп-өзеп баштан үткәннәрен аңлата.* Ш. Камал. *Мондый кыскалык, экономия, „саранлык“—вак хикәяләр язучы өчен гомумән кирәк нәрсә.* Г. Нигъмәти.

КЫСКАРТМА *и.* 1. Берничә сүзнең баш хәрефләрен генә калдырып ясалган сүз (мәсәлән, СССР, КПСС һ. б.). | *с. мәгъ. Безнең телебездә рус теле аркылы кергән кыскартма исемнәр дә кулланылалар.* Татар теле грамм.

2. Ике сүзнең аерым кисәкләрен кыскарту юлы белән ясалган кушма сүз, мәсәлән: райком, драмтүгәрәк һ. б.

3. Сүзләрнең язуда кулланыла торган махсус шартлы билгеләре, мәсәлән: һ. б. (һәм башкалар), һ. б. ш. (һәм башка шундыйлар), һ. ш. о. (һәм шуңа охшаганнар), к. (кара).

КЫСКАРТМАЛЫ *с. мат. к.* кыскартылмалы.

КЫСКАРТУ *ф.* 1. Кыскарак итү, кыска хәлгә китерү, озынлыгын киметү. *Нуруллин атыннан җиңел генә сикереп төште дә өзәңге каешын кыскартырга кереште.* А. Шамов.

2. Дәвамлылыгын киметү, срогын киметү (вакыт турында). *Эш көнен кыскарту.* □ *Утка-суга кердек, яндык, көйдек, ләкин дошман гомерен кыскарттык.* Ә. Ерикәй.

3. Нәрсәнең дә булса күләмен, микъдарын киметү, азайту. *Кулъязманың күләмен кыскарту.* □ — *Планны, сез әйткәнчә, тагын да киңәйтергә яки менә Аркадий Адольфович тәкъдим иткән күләмнән дә кыскартырга яисә бөтенләй архивка тапшырырга туры килер.* Ш. Камал. || Нәрсәнең дә булса аерым кисәкләрен төшереп калдыру. *Эчтәлекне тирәнәйтә төшәргә, образларны конкретлаштырырга, күбрәк интригә һәм хәрәкәт бирергә, артык эпизодларны кыскартырга кирәк.* М. Җәлил. || Исемнең, сүзнең бер өлешен төшереп калдырып әйтү. *Ул Газинурның исемен, башкалар кебек, кыскартып, „Газнур“ да, этисе кебек „Газизнур“ да дими, бик матур итмәгән „Газинур“ ди.* Г. Әпсәләмов. *Барыбер элекчә аны „кәкре муен Сәләхи“., яисә кыскартып, „кәкре муен“ дип кенә йөртә иделәр.* Ш. Камал.

4. *сөйл.* Штат кимү сәбәпле эштән чыгару, эштән алу. *Ләкин аңа анда озак эшләргә туры килмәс, пристаньга товар килү-китү азаю сәбәпле, грузчиклар үзара „штат кыскарту“ ясап, яңаларны артельдән чыгаралар. Хәйретдин дә „кыскартуга“ элгә.* М. Гали.

5. *мат.* Санаучысын да, ваклаучысын да бер үк санга бүлеп, вакланманың кыйммәтен үзгәртмичә кечкенәрәк саннар белән белдерү. *Вакланманы кыскарту.*

КЫСКАРТЫЛМАЛЫ *с. мат.* Кыскартырга мөмкин булган, кыскартып була торган (вакланма турында). *Кыскартылмалы вакланма.*

КЫСКАРТЫЛМАС *с. мат.* Кыскартып булмый торган (вакланма турында). *Кыскартылмас вакланма.*

КЫСКАРТЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* кыскарту.

2. *с. мәгъ.* **кыскартылган.** Кыскартуның нәтиҗәсе булган; күләме, микъдары, зурлыгы кечерәйгән; кыска. *Хикәянең кыскартылган варианты. Кыскартылган эш көне.*

3. *с. мәгъ.* **кыскартылган.** Баш хәрефләр белән белдерелгән; сүзнең бер өлеше төшерелгән. *Түбәндәге кыскартылган исемнәрне сүзлек дәфтәрегезгә күчереп языгыз.* Татар теле грамматикасы.

КЫСКАРУ *ф.* **1.** Нәрсәнең дә булса озынлыгы кимү, кыска булып калу, озынлыкка кимү. *Айның күтәрелүе белән кыскара барган агач күлгәләре Хәятның күңелендә хыялый картина тудырдылар.* Ф. Әмирхан.

2. Нинди дә булса күренешнең, эшнең һ. б. дәвамлылыгы кимү, дәвам итү вакыты кимү. *Кызыл гаскәр көчле болыт булса, Атлы гаскәр аның яшене, Бу ике көч бергә җыелганда, Кыскарадыр дошман яшәве.* М. Гафури. *Көннәр озая, төннәр кыскара, Бу кайсы вакыт, Я, әйтеп кара.* Г. Тукай.

3. *анат.* Күләм ягыннан кысылып кимү (мускуллар, тукымалар турында). *Мускулларның кыскаруы өчен энергия кирәк.* Анатомия.

КЫСКАРУЧАН *с. махс.* Кыскара ала торган, кыскару үзлеге булган. *Кыскаручан мускуллар.*

КЫСКАРУЧАНЛЫК *и. махс.* Кыскара ала торган булу, кыскару үзлеге булу (мускуллар турында).

КЫСКАСЫ *кер. сүз.* Җыеп әйткәндә, аз сүзләр белән әйткәндә, йомгаклап әйткәндә. *Кыскасы, алар пар күгәрчендәй гөрләшеп торалар иде.* Г. Бәширов. *Кыскасы, [Г. Камал] татар әдәбияты, татар сәнгате һәм гомумән татар культурасының күп кырлы, универсаль эшчесе.* М. Гали.

◇ **Кыскасы шул** — *к.* кыскасы. *Кыскасы шул, киткән чакта ул эшчеләр --- һәрвакыт без сезнең белән бергә!.. диләр.* М. Гафури.

КЫСКАЧА *с.* **1.** Озын булмаган, озынга сузылмаган. [*Халикъ белән Нәсимәнең*] *кыек сузылган кыскача күләгәләре, энҗе тузаннары өстеннән, әле бер-береннән аерылып, әле бергә кушылып, тоташ көе агалар.* Ш. Камал.

2. Кыска итеп әйтелә яки языла, кыска итеп аңлатып бирелә торган, аз сүзләр белән аңлатыла яки сөйләнә торган. [*Мотыйк:*] *Иптәшләр, монда ашлык хәзерләү, заем тарату турында базарга килгән крестьяннарга кыскача гына доклад булачак.* М. Гали. || *рәв. мәгъ.* Артык киң җәелмичә, ваклыкларга тукталмыйча, аз сүзләр белән (сөйләү, җавап бирү һ. б.). *Мостафин ашыкмыйча, никадәр ихлас күңелдән сөйләвен сиздереп торган акрын, йомшак тавыш белән Нәҗиягә үзенең үткән тормышын кыскача гына сөйләп бирде.* Э. Еники.

◇ **Кыскача (гына) әйткәндә** — *к.* кыска гына (итеп) әйткәндә. **Кыскача курс** — нинди дә булса фәннең артык киң бирелмәгән системалы курсы.

КЫСКАЧАЛЫК *и.* Сөйләүдә, язуда аз сүзләр куллану, фикерне артык җәелмичә бәян итү. *Сүздәге кыскачалык.*

КЫСКЫЧ I *и.* **1.** Миҗтән утлы күмерне, кисәүне кыстырып алу өчен металлдан эшләнгән ике япьле корал. *Кыскыч барда утка бармагың тыкма.* Мәкаль. [*Әбүгалисина:*] *Кыскычны учакка тыга.* Н. Исәнбәт.

2. Нәрсәне дә булса кысу-кыстыру яки әләктереп суырып алу өчен хезмәт итә торган кайбер җайланмаларның, коралларның исеме. *Каты селтеләрне кыскыч яки пинцет белән генә алырга.* Химия.

3. *махс.* Кысла аягының нәрсәне дә булса әләктереп алу өчен хезмәт итә торган ике япьле очы. *Кысланың кыскычы.*

Кыскыч насос *техн.* — басым көчен кулланып нәрсәнең дә булса (мәсәлән, һаваның, газның) күләмен кечерәйтә торган насос. *Газларны егәрле кыскыч насослар — компрессорлар ярдәмендә кысалар.* Физика.

◇ **Кыскычка алу, кыскыч эченә алу** — камап алу, блокадага алу. *Немецлар --- Мәскәүне бик зур „кыскыч" эченә алырга омтылдылар.* СССР тарихы.

КЫСКЫЧ II *и. иск.* Кысла. *Бервакыт Аккош, Чуртан, Кыскыч — өчесе дә бер йөккә җигелеп, аны алга алып бармакчы булдылар.* Г. Тукай. *Каз үзенең бәбкәсен төрлечә сыйлап карый икән: тәмле-тәмле бакалар, татлы кыскычлар тотып китерә икән.* А. Алиш.

КЫСЛА *и. зоол.* Башы янында кыскычлары булган, кабырчык белән капланган, умырткасыз төче су хайваны. *Балыклар кысланы --- яратмый.* М. Гафури. *Аяклары ярдәмендә кысла су төбендә шуышып йөри ала.* Зоология.

◇ **Кысланың кайда кышлаганын күрсәтү** — бик нык янауны белдерә. [*Дсир:*] *Бәхетең, Потапов качып өлгерде. Югыйсә, ул сиңа күрсәтер иде кысланың кайда кышлаганын.* Н. Дәүли.

КЫСЛАНКЫ *и. диал.* Чәчелми калган җир, кысыр җир.

КЫСЛАСЫМАННАР *и. зоол.* Гәүдәсе кабырчык белән капланып сегментларга бүленгән, аяклары бик күп буынтыклардан гыйбарәт хайваннар классы. *Елга кысласы, дафния --- буынтыгаяклыларның кысласыманнар классына керәләр.* Зоология.

КЫСМА: кысма куныч — оекның, бияләйнең һ. б. ның тартканда беркадәр киңәя, бушатканда яңадан кысыла төшә торган итеп бәйләнгән өлеше. [*Нәфисә*] *Перчаткалар бәйли матур итеп, Сырлы итеп кысма кунычын.* Э. Ерикәй.

КЫСМАЛАУ *ф.* Чыбык-чабыкны һ. б. ш. бергә китереп бәйләү. *Хәтта аның идәннәре, түшәмнәре, ишекләре һәм лаукаларе дә кысмалаган чыршы ботагыннан гына ясалган иде.* М. Гали.

КЫСМЫР: кысмыр кеше *диал.* — саран кеше.

КЫСРЫК *с.* Урыны, мәйданы тар, кечкенә булган, пространствосы тар булган. *Кысрык урам. Кысрык бүлмә.* □ *Тар, кысрык ишек алларында яссы гәүдәле, салынкы корсаклы дуңгызлар йөри.* А. Шамов. || *и. мәгъ.* Тар урын, пространствосы аз урын. *Бу һава, бу яз галәмәте кешеләрне урамнарга тарта, кысрыктан иркенгә өстери.* Ф. Әмирхан.

КЫСРЫКЛАУ *ф.* **1.** Кешене яки хайванны нинди дә бер җиргә, почмакка китереп кысу, аңа ычкынырга ирек бирмәү. [*Шәпеш*] *малайны аягы белән почмакка кысрыклап тоткан хәлдә ул кәгазьне актарып карады.* Ә. Фәйзи. *Әлмәш бабай бәрәнен бер почмакка кысрыклады.* Ф. Кәрим.

2. Урын аз калдыру, тыгызлау. *Чабышучыларны күрергә ашкынган халык, тегеләр киңәйтергә тырышкан саен, юлны һаман кысрыклап баралар.* М. Гали. || Тыгызлана-тыгызлана урын калдырмау; кыса-кыса (этәрә-этәрә) тыгызлык барлыкка китерү. [*Пароходта*] *бары тик бер-берсен кысрыклаучы гәүдәләрнең тыгыз хәрәкәте белән, ишле ютәл аралаш, аерым сүзләр генә яңгырап киткәли иде.* К. Нәҗми.

3. Һөҗүм итеп чигендерү, чигенергә мәҗбүр итү (гаскәрләр турында). *Дошман десантын, иртә белән куе урманга кысрыклап, яртылаш тар-мар итү --- мөмкин булды.* Ш. Маннур. *Сагынып көткән кызыл частьлар, партизан отрядлары Агыйдел буеннан интервентларны, ак банданы кысрыклап куып килләр.* Г. Гобәй. || Кыен хәлдә калдыру (уенда). [*Шәрәфи агай*] *Солдат ягыннан төшеп, Гарифны бер-ике мәртәбә рәттән кысрыклап җиңделәр.* Ш. Камал.

4. *күч.* Кемне дә булса берәр эш башкарырга мәҗбүр итү. *Һичбер көчләү, һичбер кысрыклаусыз, Ба-*

ры сине тирән сөйгәнгә — Йөрәгемне сиңа бирмәдемме? М. Җәлил.

5. Сүз белән һөҗүм итү, тәнкыйтьләү. *Ферманың азмы-күпме уңышларын телгә алып сүзен башлаган яшь председатель акрынлап, ләкин эзлекле һәм рәхимсез рәвештә ферма мөдирен кысрыкларга тотынды.* Ә. Еники.

6. *күч.* Кысу, изү. *Капитализм тормышы кысыклавы белән имениеләрен сатып бөлгенлеккә барган алпавытлар [„Чия бакчасы"], җир-көннән аерылган крестьяннар, тагын --- бик күпләр --- Чехов әсәрләрендә --- очрыйлар.* Г. Нигъмәти. || Җәберләү, рәнҗетү. *Кызны бик кысрыклаганнар.* Ф. Әмирхан.

7. *күч.* Бер уйны, хисне һ. б. башка бер уй, хис һ. б. алмаштыру; нинди дә булса бер уйны, хисне баштан чыгару. *Аның борынгы тәмле уйлары урынына икенче уйлар урнашып, теге уйларны, борынгы хыялларын кысрыклап бәреп чыгардылар.* М. Гафури.

КЫСРЫКЛЫК *и.* Кысрык булу, пространство аз булу. *Бүлмәнең кысрыклыгы.*

КЫСРЫНКЫ *с. диал. к.* кысрык. *Бары шәһәрдә толчок базарында мондагы шикелле кысрынкы була.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КЫСТАЛУ *ф.* 1. *Төш юн. к.* кыстау.

2. Тышка чыгасы килү, табигый ихтыяҗны канәгатьләндерәсе килү. *Мирәли поезддан төшкәннән бирле кечкенә йомыш белән кысталып бара иде.* Г. Гыйләҗев. || Бала тудыру вакыты җитү, шундый халәт барлыкка килү. *Үзенең дә бер дуңгызы балаларга кысталып йөри иде.* Р. Төхфәтуллин.

КЫСТАТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* кыстау.

2. Кат-кат үтенергә, сорарга мәҗбүр итү (кемнең дә булса ашарга үтендерүе турында әйтелә). *Кунак шикелле, без кыстатып торырга белмибез, алга нәрсә килсә, табак төбе күренгәнче, шуны ялтыратма гына бирәбез.* М. Гали. || Гомумән, нинди дә булса бер эшне эшләү өчен кат-кат үтенергә, сорарга мәҗбүр итү. [*Әсма:*] *Я, җырла инде, нигә җырламыйсың. Мин үзем җырлый белсәм бер дә кыстатмас идем.* Г. Ибраһимов.

КЫСТАТУЧАН *с.* Кыстата торган.

КЫСТАУ *ф.* 1. Ашарга-эчәргә үтенү, сорау. *Газизә апа олаучыны кыстый-кыстый чәй эчерә һәм Габдулла турында сораштыра.* Ә. Фәйзи. *Әби Рифгатьне кыстый-кыстый сыйлады.* А. Әхмәт.

2. Гомумән кемне дә булса берәр эш эшләргә кат-кат үтенү, сорау. *Кызлар аны үзләренең уеннарына катнаштыралар, аны кыстап, курай уйнаталар иде.* Ф. Әмирхан.

КЫСТЫБЫЙ *и.* 1. Уртага бөкләнгән юка камыр эченә изгән бәрәңге, тары боткасы, төелгән киндер орлыгы яки мәк орлыгы һ. б. салып пешерелгән ашамлык. [*Халикъ:*] *Мин үзем дә Нәсимәгә кыстыбый пешерергә кушып киткән идем.* Ш. Камал. *Бәдри ашый башлады. Бәрәңге кыстыбые, ахры. Бик йомшак.* И. Гази.

2. *күч. сөйл.* Башка кешеләрнең эшенә яки сөйләшүләренә кысылырга, катнашырга ярата торган кеше. [*Зөлхиҗә:*] *Кысылма, кыстыбый.* И. Туктар. || Әһәмиятсез, вак кеше турында. [*Вәли:*] *Аннан теге яңа килгән кыстыбыйлары да һөнәрләрен күрсәтәчәкләр.* Т. Гыйззәт.

КЫСТЫРГЫЧ *и.* 1. Юылган керне һ. б. ш. бауга беркетү өчен кечкенә бер әсбап; кер эләктергеч. || Гомумән, нәрсәне дә булса кыстыру, кыстырып кую өчен агачтан яки металлдан ясалган әсбап.

2. *тех.* Слесарьлык эшендә: эшкәртелә торган предметны беркетеп куя торган җайланма; *русчасы:* тиски.

3. *физ.* Үткәргечләрне машинага, приборга, аппаратка һ. б. ш. беркетү өчен җайланма, клемма.

КЫСТЫРУ *ф.* 1. Бармакны, аякны һәм, гомумән, тәнне берәр нәрсә арасында калдырып авырттыру. *Кулны кыстыру. Аякны кыстыру. Бармакны кыстыру.* □ *Ат аягын дагалаганда, бака ботын кыстыра.* Әйтем.

2. Нинди дә булса тар, кысан җиргә берәр нәрсәне тыгызлап кертеп кую, этәреп кертү. *Миңнулла чыбыркысын биленә кыстырып куйды.* И. Гази. [*Яшь егет*] *бер сумны алып жилетка кесәсенә кыстыра.* Г. Камал. || Киемнең чабуларын, күлмәкнең итәкләрен һ. б. бөкләп билбау, каеш астына кертеп тоттырып кую. [*Карт*] *аннан соң җайлап кына бишмәт чабуларын кайтарып, билбавына кыстырды.* М. Гафури. *Күлмәк итәкләрен кыстырган ябык гәүдәле, әрлән кебек җитез яшь кенә хатын иде ул үзе.* Ә. Фәйзи. || Одеялның һ. б. ш. чит-читләрен бөкләп астына тыгып кую. *Аннары* [*сестра*] *Нуруллин баш астындагы мендәрне уңайлады, одеял кырыйларын кыстырды.* А. Шамов. || Кирәкмәгәндә ачыла торган ишек, капка кебек предметлар арасына берәр нәрсә тыгып куеп тиешле тыгызлык барлыкка китерү. *Өйнең стеналары алга таба рекугыга киткәнлектән, ишекне бер дә әйбер кыстырмый ябар хәл юк, хәзер ачылып китәдер иде.* М. Гали.

3. Нәрсәне дә булса ике яктан китереп кысу, кысып тоту яки кысып тоттыру. *Бикбулатов нечкә бармакларына кыстырып, конверт эченнән кыска гына язылган хатны тартып чыгарды.* А. Әхмәт. || Култык астына алу, култык астына алып кысып тоту. *Тальянымны кыстырдым да чак-чак килеп өлгердем.* М. Җәлил. *Култык астына капчыклар кыстырган Сәлимҗан завхоз янына килгәч, завхоз сул кулы белән аңа амбар ишеген күрсәтә.* А. Алиш.

4. Өй сипләгәндә иске, черек бүрәнәләрен алып, яңа бүрәнәләр кую. [*Агай:*] *Менә* [*стенаның*] *шул җирләре җәй көне тәмам кибеп ачылган иде. Узган атна гына әле бик һәйбәт кыстырып төзәттердек.* Ш. Камал.

5. Берәр нәрсәне кемнең дә булса кулына тоттыру, бирү. *Шул арада Сиражетдин бик кечкенә җтеп бөкләнгән биш йөзлекне докторның кулына кыстыра.* Г. Камал. || Нәрсә дә булса бирү, биреп җибәрү. *Зәйнәпбануның әнисе: „Йөрәгең бик өзелгәндә кабып җибәрерсең" дип, бераз әремчек кыстырган икән, аны да куйдылар.* Г. Бәширов.

6. *сөйл.* Кемне дә яки нәрсәне дә булса исемлеккә теркәү, кертү яки берәр нәрсәгә катнаштыру. *Туймазар була калса, Илдар, мөгаен, исемлеккә Зифаны кыстырмый калмас.* Г. Гобәй.

7. Сөйләп яки язып барганда үзенчәлекле булган сүз, фикер әйтү, өстәү. *Матур гына мактап киләләр дә Иң ахырда „ләкин" сүзен кыстырып куялар.* һ. Такташ. || Берәр кеше сөйләп яки кешеләр сөйләшеп торган вакытта читтән нинди дә булса берәр сүз әйтү, берәр сүз өстәү; сорау бирү. *Мин үз авылыбыз турында сөйлим, ә ул күрше авылларны китереп кыстыра.* Ш. Камал. *Әмма шаяртып кына әйткәндәй арага кыстырып җибәргән берәр сүзе --- бөтен халыкның башын әйләндерә, гайрәтен чигерә торган иде.* Г. Бәширов.

8. *сөйл.* Эләктерү, алу (култыкка). *Нечкә сыйраклы нәрсәсен култыгына кыстыра да, театрына китә, бакчасына чыгып китә.* Г. Ибраһимов.

КЫСТЫРУЛЫ *с.* Билбау, каеш астына кертеп эләктерелгән, эләктереп куелган (кием чабуы, күлмәк итәге һ. б. турында). *Кулен үзе дә җиңнәрен сызга-*

нып алган, итәк кыстырулы, кулы кулга йокмый. Ф. Хөсни.

КЫСТЫРЫНУ *ф. сөйл.* Үзеңнең итәкләреңне, чабуларыңны кыстыру. *Каршына Мәрфуга килә. Итәген кыстырынган.* М. Фәйзи.

КЫСУ *ф.* 1. Нинди дә булса бер авырлык, көч белән басу, йогынты ясау. [*Әметбаев*] *фураж касын салып атты да, бөтен көчен җыеп --- пружинаны замокка кысып кертергә тотынды.* Г. Гобәй. || Тыгызлау, тыгызлык барлыкка китерү. [*Җыелышта*] *Тыгызлана ара, Арка тала, өелделәр, арттан кыстылар.* М. Җәлил.

2. Кемне яки нәрсәне дә булса куллар белән уратып алып тоту. *Апасы шунда ук аны кочагына кысып алды һәм әнесенең битләреннән, күзләреннән үпте.* Ә. Фәйзи. || Нәрсәне дә булса кулның учы, бармаклары белән каты итеп тоту. *Хәлим, себеркесен каты кысып, керфеген дә какмыйча көтә.* И. Гази. [*Әлфия*] *озак та тормады, чыгып Саниянең беләген кысты.* Г. Бәширов. || Нәрсәне дә булса (мәсәлән, күзләрне) куллар белән каплау. *Әсма --- ике кулы белән аның күзеннән кысып тотты.* М. Гали. *Сафа, җиргә тезләнеп, куллары белән Газизнең күзләрен кыса.* Ф. Әмирхан. || Нәрсәне дә булса тешләр белән каты итеп тоту. *Тычкан, --- башагын тешләре белән ныгытыбрак кысып, үләннәргә бәрелә-сугыла, тәгәрмәч уйган канау буйлап йөгерде.* Г. Гобәй.

3. Сәламләү, саубуллашу, тәбрикләү йөзеннән кемнең дә булса кулын билгеле бер рәвеш белән тоту. *— Саумы, Мәдинә! — диде Сәйфулла һәм кызның кулын каты итеп кысты.* Ә. Еники.

4. Кемне яки нәрсәне дә булса күкрәккә китереп терәү. *Хатны кысып күкрәгенә, үкси бичара ана.* М. Җәлил. *Сәҗидә бик аз гына карап торды да төенчекне күкрәгенә кысты.* А. Әхмәт. || Ике предметны бер-беренә якын китерү яки тидерү. *Мин акрын гына болар янына килдем дә ике кулым белән икесенең башларын акрын гына бер-берсенә кыстым.* Ф. Әмирхан.

5. Берәр нәрсә янына китереп камау, китереп терәү, аннан чыгарга ирек бирмәү. *Ул арада атлар, өркеп китеп, аны ике арба арасына китереп кыстылар.* А. Шамов. *Барын, сарык көтүе кебек, чиләкләре, читекләре белән тар бер почмакка китереп кысалар да тенти башлыйлар.* Г. Ибраһимов. || Нәрсәне дә булса уратып ала бару. *Аждаһалар аждаһасы үзенең кармавычлары белән блокаданы кысканнан-кыса барды.* Г. Гобәй. || Төрле яктан басым ясап камап алу, камап алып чыгарга ирек бирмәү. *Седовның „Фока“ исемле корабын бозлар кысалар, бер ел буе беркая җибәрми, бер урында гына тоталар.* А. Алиш.

6. *күч.* Нәрсәне дә булса бик нык чикләү, берәр яктан бик авыр хәлгә кую. [*Галимҗан:*] *Әгәр финанс ягыннан кысмасалар, каты авыру өчен дәваланырга кирәк булганын тоткарсыз җибәреп торсалар, терелермен.* Ш. Әхмәдиев. [*Карип:*] *Алиш мине кыса. Минем язганнарны гәзиткә һәм әдәби журналга кертми калдыру ягын карый.* Ш. Маннур.

7. Ачу, нәфрәт һ. б. ш. билгесе буларак, иреннәрне, тешләрне бик каты итеп бер-беренә тидерү, тидереп кую. *Бирешмәскә тырышып иреннәремне кыссам да, көчем җитмәде, иреннәрем калтыранды.* М. Гафури. *Миңнур карт исә, нәрсәнедер яратмыйча, кашларын җыерды, тешләрен кысты, һәм аның яңак сөякләре очлаеп калкып чыкты.* А. Шамов. || Нәрсәне дә булса (мәсәлән, бармакларны) бергә китереп бик каты итеп йому. [*Габдулла*] *йодрыкларын кысып аңа якынлый.* Һ. Такташ. || Берәр нәрсәне учка алып йому. *Ул [бодайны], нечкә мыегын кыймылдата-кыймылдата, озаклап иснәде, тешләп карады, берәмләп санап чыкты, учында кысып дымын чамалады.* Г. Бәширов.

8. Нәрсәне дә булса хәрәкәткә китерү өчен аның җибәрү механизмына басу, басым ясау. *Летчик шулай диюгә, ромблы кеше гашеткаларны кысты.* Г. Гобәй.

9. Кысан булу, тар булу; кысан яки тар булу аркасында тәнне авырттыру (аяк киеме, күлмәк һ. б. турында). *— Нихәл, егетләр, җиләнә кысмыймы?* Г. Камал. *Иске читекләр өстенә кигән яңа чабаталар, ике-өч чакрым җир киткәнче үк, шешенеп, аякларны кыса башладылар.* М. Гафури.

10. Бик нык тартып яки тарттырып бәйләү, буу. *Ул билендәге [каешын] ныклабрак кысты, кызыл тәреле сумкасын рәтләде һәм Салават аерып куйган патроннарны җитез генә кулына алды.* А. Шамов. *Барыгыз да яшел киенгәнсез, Билегезне кысып бугансыз.* М. Җәлил.

11. (Ишекне һ. б. ш. ачыла-ябыла торган әйберләрне) бик аз гына ачу, ачып кую яки беркадәр ара калдырып ябу. *Сәрви сикереп торды һәм барып ишекне кысып кына ачып куйды.* Ә. Фәйзи. *Умартачы бабай зәңгәр йортның ишеген кыса төшкән, моның белән нечкәбилгә бик зур ярдәм иткән.* А. Алиш. || Лампа һ. б. ш. филтәсен төшереп, яктырту көчен киметү. [*Хәкимҗан абзый*] *лампа янына барды, аны югарырак алып әлде һәм сүнәр-сүнмәслек итеп кысып куйды.* А. Шамов.

12. Мичкә, кисмәк, идән һ. б. ш. такталарын ярык калмаслык итеп тыгызлау. [*Ярулла:*] *Менә бит, төбен кыскач, кыршавын суккач, шап-шактый кисмәк булды.* Ф. Бурнаш.

13. Киметү, азайту (күләмен, микъдарын һ. б.). *Картиналарның санын киметеп, вакыйганы шактый кыса төшәргә кирәк.* М. Җәлил. || Экономияләү, чыгымнарны бик нык киметү. *Хак зур булмаса да, ашаудан кысып, көненә унбишәр сәгать эшләп, айга егерме биш сумнар калдырырга чама бар иде.* Г. Ибраһимов.

14. Сулыш юлын тыгызайту, сулышны авырайту. *Үлем ашыгып кайнар сулыш юлын кыса.* М. Җәлил. || Нинди дә булса бер авырлык, авырту тою турында (күкрәктә, йөрәктә). *Тын алуы читен, күкрәк кыса, әйтерсең лә һава юк хәзер.* М. Гафури. *Ә ачу йөрәкне кыса, суларга ирек бирми, укмашып, бугазга тыгыла, ташып чыгарга, шартларга ашкына.* А. Шамов.

15. *спорт.* Штанганы, герне һ. б. ш. салмак кына баш өстенә күтәрү. *Кысуда күтәрү максаты штанганы күкрәккә алу булса, биредә күтәрү дәвамында штанга астына чүгәләргә кирәк.* Соц. Тат.

16. *физ.* Басым белән тәэсир итеп күләмен кечерәйтү (газ, сыеклыклар турында). *Компрессорлар ярдәмендә газны меңнәрчә атмосфера басымга кадәр кысарга була.* Физика.

17. *күч.* Нәрсәне дә булса эшләргә яки сөйләргә, нәрсәне дә булса бирергә мәҗбүр итү, нәрсәне дә булса бик каты талән итү. *Кыса торгач, [ул] сөйләп бирергә мәҗбүр була.* Ф. Хөсни. *Шихрай, Фәтхинең киңәше буенча, райпрокурорга Нәгыймне ныграк кысу кирәклекне әйткән булса да, аның нәтиҗәсе күренмәде.* Ш. Камал.

18. *күч.* Бик каты изү, эксплуатацияләү; ирекле яшәүгә, эшчәнлеккә, үсешкә мөмкинлек бирмәү. *Патша жандармериясе, аның сатлык агентлары татар халкының алдынгы вәкилләрен күпме генә кысмасыннар, күпме генә җәберләмәсеннәр, алар үзләренең идеалларына турылыклы булып калдылар.* Каз. утл. || Җәберләү, рәнҗетү, кимсетү. [*Арджанов Гайшә*

Үзенең бәйләнчек табигате белән сезне бик кысмый идеме? Г. Ибраһимов.

Кысып алу — берәр предметны нәрсә белән дә булса тоттырып алу. [*Зөһрә*] *тимерне учактан келәшчә белән кысып алып сандалга куйды.* Г. Гобәй. **Кысып чыгару** — 1) берәр нәрсә эчендә булган сыеклыкны сыгып чыгару. *Лимоннан сок кысып чыгару;* 2) әкрен генә яки теш арасыннан нинди дә булса сүз әйтү яки җырлау. [*Габдулла*] *яңакларын тыны белән кабартып, иреннәреннән ниндидер сагышлы көй кысып чыгарырга тотынды.* Ә. Фәйзи.

КЫСУЧЫ 1. *с. ф. к.* кысу.

2. *и. мәгъ. сөйл.* Изүче, эксплуататор. — [*Рус, татар алпавытлары һәм промышленниклары*] *бергәләшеп, һәм рус, һәм татар крестьянын, эшчеләрне кысмыйлармы, кысучыларның һәр икәвесен хөкүмәт яклап килмәдеме, хәзер дә якламыймы?* Ш. Камал. || Җәберли, кимсетә торган кеше. *Бу юлда шаула, матбугат! Хатыннарны кысучыларга каршы ач сугыш, ук ат!* Г. Тукай.

КЫСЫК *с.* 1. Кысан, кысрык, тар (бина, коридор һ. б. турында). *Кысык коридор.*

2. Филтәсе төшерелеп, яктырту көче кимителгән (лампаның һ. б. ш.). *Вәли бай йортындагы кысык ут шәүләсеннән башка, авылда бер яктылык та күренми.* Һ. Такташ.

3. Тешләрне кысып әйтелгән, түбән тавыш белән әйтелгән. [*Хәдичә*] *пышылдауга якын бер кысык, азаплы тавыш белән: — Инде булмый, — диде.* Г. Бәширов.

Кысык күз(ле) — күз кисеме тар булган, күз кисеме кысылыбрак торган. [*Карт*], *өлкән сержантның ни сөйләгәнен аңларга теләгәндәй, үзенең кара кысык күзләре белән аңа җылы, якын итеп карап тора иде.* А. Шамов.

КЫСЫКЛЫК *и.* Кысык булу, тар булу. *Коридорның кысыклыгы.*

КЫСЫЛА-КЫСЫЛА *рәв.* Берәр бик тар урын аша яки бик күп кешеләр арасыннан тыгызланып үтеп. *Шул сыныкрәшәткә арасыннан кысыла-кысыла каток эченә кереп киткәнен ул үзе дә сизми калды.* А. Шамов. [*Фәхри*] *партер ишеге төбенә аягүрә басып тыгылган халыкны ерып этәреп, кысыла-кысыла фойега чыкты да Гәүһәрләр утырган ложага таба борылды.* Г. Ибраһимов.

КЫСЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* кысу (7, 9 мәгъ. башка).

2. Күләме, зурлыгы ягыннан кечерәю. *Җирнең өс кабыгы, эчендәге матдәгә караганда тыгызрак булганга күрә, акрынрак кысыла.* Ф. Әмирхан. [*Кызыл-армеецлар тарафыннан*] *провокаторны әйләндереп алган бөжра кысыла барды.* Г. Гобәй. | *физ.* [*Күп баскычлы компрессорларда*] *газ бер-бер артлы өчдүрт цилиндрда кысыла.* Физика.

3. Бик тыгыз тоташу (иреннәр, тешләр турында). *Утюгны ныклап торып баскан саен,* [*Газизәнең*] *озын керфекләре тетри, матур иреннәре ныграк кысыла.* Ш. Камал. *Сабираның күзләре чытырдап йомылган, кипшенгән иреннәре ачылган, тешләре кысылган.* Ә. Фәйзи. || Беркадәр йомылу (күзләр турында). *Бары тик кысыла төшкән күзләре генә* [*Зарифның*] *эчке уйларга йотылып баруын күрсәтәләр.* Ә. Еники. || Бармаклар йомарлану, уч йомылу. *Тимеринең борын төбендә кодасының чытырдап кысылган кечкенә көрән йодрыгы ялтырап тора.* Г. Бәширов.

4. Ике яктан кысу, басым ясау аркасында эләгү, эләгеп калу (ярыкка, капкынга һ. б. ш.). *Төлке кетәклеккә керим дигәндә генә, капкын „шап“ итә. Төлкенең аягы кысыла, ул чыелдый.* А. Алиш. *Шүрәленең бармагы калды, кысылды „шап“ итеп.* Г. Тукай. || Ике предмет арасында булу, ике яктан уратып алыну, камап алыну. *Ике фанза арасына кереп кысылган капкалар янында ак ташлар өелеп тора.* А. Шамов. *Ул вакыт без тирмәндә яшәдек, бер ягыбыз — яланғач, соры ташлары белән күккә күтәрелгән зур тау; икенчесе — көне-төне шаулап утырган карацгы урман. Без табигатьнең шул ике куәте арасында кысылганбыз.* Г. Ибраһимов. || Кая да булса кереп эләгеп калу. *Тешкә ит кысылу.* || Тыгызланып керү. *Менә шундый чиратларның берсенә Шәйдук карт та килеп кысылды.* К. Нәҗми.

5. Филтәсе төшерелеп, яктырту дәрәҗәсе кимү (лампа һ. б. ш. турында). *Ул арада өй эчендә кысылып кына янып тора торган кечкенә асылмалы лампадагы ут та күтәрелде.* М. Гали.

6. Сулыш тыгызлану, сулыш алу кыенлашу турында. *Сулыш кысылу.* □ *Нәфисә, тыны кысылып, теле тотлыгып, баскан урынында катып калды.* Г. Бәширов. || Берәр төрле авырлык, авырту сизү (йөрәктә, күкрәктә). *Йөрәгем курку вә сызлану катыш бер тойгы белән кысылды.* Ф. Әмирхан. *Йөрәк кысыла әрнеп, Чөнки анда бүген туган илем яралы.* М. Җәлил.

7. *күч.* Кемнең дә булса эшләренә, үзара мөнәсәбәтләренә тыгылу, катнашу. [*Нәсимә:*] *Мәхәббәт эшенә тыгылма син, зур нәрсә ул мәхәббәт. Өченче берәүнең кысылуы аны хурлау гына дигән сүз.* Р. Ишморат. [*Әпипә:*] *Ир белән хатын арасына килеп кысылмасаң, эшең беттемени?* Г. Бәширов. || Сөйләшеп торган вакытта сүзгә кушылу. *Кулына бер бөтен бәрәңге тотып өлгергән Халикъ яңадан сүзгә кысылды.* Г. Әпсәләмов. — *Ашый торган балчык бар икән, — дип, кайсыдыр арага килеп кысылды.* И. Гази. || Арага нинди дә булса бер эш килеп кереп, икенче бер эшкә комачаулау турында. *Арага бер эш кысылу.*

8. *күч.* Нәрсә белән дә булса чикләнү, тоткарлану, үсә алмау турында. *Шулай итеп, аның эчендәге музыка дөньясы, музыкадан ләззәт алу өчен яратылган тойгылары күп елларгача шәкерт вә мәдрәсә галәменең куәтле рамкалары эченә кысылып, әллә кайда, төптә, рухының әллә нинди эчке катлауларында бикләнеп ятырга мәҗбүр булалар.* Г. Ибраһимов.

9. *күч.* Берәр әйбер кимү, бик аз калу; берәр әйберне табуы авырга әйләнү. [*Директор:*] *Без кисә торган утынның күбесе хәрби паровозларны йөртергә китә. Үзегез беләсез, ташкүмер ягы кысылды.* Г. Гобәй.

Кысылып чыгу — акрын һәм түбән тавыш белән сөйләү яки әйтү. *Аның кысылып чыккан һәм шул ук вакытта ягымлы тавышы Хәдичә түтинең йөрәгенә барып тиде.* Г. Бәширов.

КЫСЫЛУЧАНЛЫК *и. физ.* Тышкы басым нәтиҗәсендә матдәнең үз күләмен кечерәйтә алу сәләте. *Газларның кысылучанлыгы.*

КЫСЫЛЫП *рәв.* 1. *к.* кысыла-кысыла. *Куркү күңелемә килмәде, тар тишектән кысылып эченә төштем.* Г. Ибраһимов. || Тыгызлашып, бер-берсен тыгызлап. [*Миңлегали:*] *Сыярлар, Вилдан абый. Егетләр бит алар кысылып утырырга өйрәнгән булалар.* Ф. Бурнаш.

2. *күч. сөйл.* Бик акрын тавыш белән. *Аның героик сүзләре дә вакыт-вакыт, ничектер кысылып, сер сөйләгәндәй акрын әйтеләләр.* М. Җәлил.

КЫСЫЛЫП-КЫСЫЛЫП *рәв. к.* кысыла-кысыла. *Халык кысылып-кысылып чыга башлады.* Ф. Әмирхан.

КЫСЫЛЫШ *и. сөйл.* Берәр эшкә мөнәсәбәт, бәйләнеш. *Аның бу эшкә кысылышы юк.*

КЫСЫЛЫШУ *ф.* Тыгызланышып бер-беренә бик якын килү. *Сул якның алдагы рәтендә Бикбулат*

кодасы белән ак сакаллы Айтуган карт, кысылышып, Тимеригә урын бирделәр. Г. Бәширов.

КЫСЫМ *и.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса басым ясау; һөҗүм. *Кызыл Армия --- акгвардиячеләрнең кысымын уңышлы рәвештә кире какты.* КПСС тарихы. [*Анархистлар*] *дезорганизация генә кертәчәкләр; моның белән алар гомуми кысымның көчен йомшартачаклар.* В. И. Ленин. || Изү, кысу. *Эшчеләр буржуазиянең кысымын кире кага бардылар.* КПСС тарихы.

КЫСЫНКЫ *с.* **1.** Кысан, тар; кечкенә (бина, бүлмә һ. б. турында). *Безнең өй кысынкы, тәрәзәләре дә кояшка карамый.* Ә. Фәйзи. || Аякны, тәнне кысып тора торган (аяк киеме һ. б. турында). *Кысынкы ботинкалардан юка, саргылт оек эчендәге кечкенә генә нәфис аяклар килеп чыктылар.* Ф. Әмирхан. || Күз кисеме тар булган, күз кисеме кысылыбрак торган. [*Асрау карчыкның*] *күзләре кечкенә, кысынкы.* Г. Коләхметов.

2. Авыр шартлардан гыйбарәт; ирекне, шәхесне кысучы (тормыш турында). [*Думбрачы егетнең*] *сүзләреннән бертөрле кысынкы тормыштан ялыгу, икенче тормышка талпыну да --- сизелә иде.* М. Гафури. || Катгый, чыгармалары булмаган (таләпләр, кагыйдәләр һ. б.). *Хәзрәтнең кысынкы кагыйдәләре эчендә яшәгән шәкертләр --- башларына килгән һәрбер эшләрне кыла башладылар.* Г. Ибраһимов. *О, кайгәр төшкән кысынкы тәкәллефләр, нигә сез яшисез дә, нигә Рахильнең яшь йөрәген тураклыйсыз, нигә аның иң саф, иң матур хисләренә ташып чыгарга ирек бирмисез!* А. Шамов.

3. *сөйл.* Берәр нәрсә дә булса җитмәү, бик аз булу турында. *Акча кысынкы вакыт.* ▭ *Тик* [*Зәбировның*] *вакыты гына бик кысынкы.* Г. Әпсәләмов.

4. *мат.* Туры почмактан кечерәк булган. *Кысынкы почмак.* ▭ *Барлык почмаклары кысынкы булган өчпочмак кысынкы почмаклы өчпочмак дип атала.* Геометрия.

5. *рәв. мәгъ.* Экономияләп, бик аз тота-тота. [*Шәриф:*] *Җитәр инде, телмә! Кич ашап ятарлык калсын, --- азрак кысынкырак ашарга кирәк.* М. Гафури.

КЫСЫНКЫЛАНУ *ф. сөйл.* Авырлашу, кыенаю. *Тормыш кысынкылану.*

КЫСЫНКЫЛЫК *и.* **1.** Кысынкы (1 мәгъ) булу.

2. Изелү, эксплуатация. *Патша Россиясендә яшәгән башка милләт ияләре кебек үк, татар хезмәт ияләре дә зур кысынкылык эчендә яшәп килделәр.* М. Гали. || Ирек һ. б. яклардан чикләнгән булу. — *Кәбиров ничек уйлый икән: ул кысынкылык, ул җәфалар, ул наданлыклар милләт дигән нәрсәнең бөтен катлаулары өлешенә тигез төшкән бәхетсезлекме?* Ш. Камал. || Тормыш авыр булу; нәрсә дә булса җитмәүчелек, мохтаҗлык. *Яшәмиләр хәзер тоткынлыкта, Көн күрмиләр кысынкылыкта.* М. Гафури. *Тукай 1907 нче елның башында бөтенләй эшсезлек һәм гадәттән тыш материаль кысынкылык эчендә кала.* Г. Халит.

2. Яшәешнең, тормышның каты рамкалар эченә алынуы; артык каты дисциплина. [*Гариф солдат:*] *Башка вакытта безнең кысынкылыкны алла күрсәтмәсен, кайда ул болай читтә кунарга китә алу!.. Урамга да рөхсәт белән чыгарга кирәк.* М. Гафури. || Шәхескә үсәргә ирек бирмәү. *Зыя иске мәдрәсәне яратмый, аның кысынкылыгыннан тарлана, ташлап чыга.* Г. Нигъмәти.

3. Кешеләр төркеме эчендә, чиратта барлыкка килгән тыгызлык, урын булмау. *Пристаньдагы халык касса тирәсенә җыела башладылар, бер дәкыйка эчендә өченче класс билетларының касса тәрәзә төбендә нибаять дәрәҗәдә бер кысынкылык тәшкил итте.* Ф. Әмирхан.

КЫСЫП-КЫМТЫП *рәв.* Аз-азлап, экономияләп, нәрсәдән дә булса бүлеп алып (җыю, туплау һ. б.).

КЫСЫР *с.* **1.** Тумасы булмаган, үрчем бирмәгән, аталанмаган (терлек турында). *Кысыр сыер. Кысыр сарык.* ▭ *Араларында ике кысыр бия, берничә яшь айгыр, унлап тай бар иде.* Г. Ибраһимов. || Җимеш бирми торган. *Кысыр чәчәк.*

2. Эшкәртелмичә ташланып торган, ташланып калдырылган, иген чәчелмәгән (басу, җир турында). [*Биктимер:*] *Бернигә карамыйча, алпавыт Кригерның кысыр басуын өләшеп чәчтерер идем.* Т. Гыйззәт. *Кая соң монда кызыл ярлы тирән чокырлар, элекке кысыр һәм шыксыз тау кырыйлары?* Г. Бәширов.

3. Дары белән генә корылган, пулясы булмаган (патрон, заряд турында). *Кысыр патроннар.* ▭ *Архангельский --- күк гөрелтеләр, яшеннәр чәчә иде. Ләкин эшкә җитдирәк караучы халыклар күптәннән инде "ул гөрелтеләргә „кысыр патроннар гөрелтесе" дип карыйлар иде.* Ш. Камал.

4. Итсез пешерелгән, ите булмаган (аш турында). *Кысыр кәбестә ашы.* ▭ *Умачны итле, сөтле һәм шулай ук кысыр ашларга да салалар.* Татар халык ашлары.

Кысыр болыт — яңгырсыз, гомумән явым-төшем барлыкка китерми торган болыт. [*Сөләйман*] *кысыр болытларга охшаган --- уйларын бергә җыйнап, билгеле бер юнәлешкә әйдәүче көчле давылның кирәклеген ачык төшенде.* К. Тинчурин. **Кысыр калдыру** — чәчми калдыру. [*Мәүлиха түти:*] *Икмәк шундый кирәк чагында, сугыш вакытында басуны кысыр калдырсаң, җир йотар үзеңне.* Г. Бәширов. **Кысыр калу** — тума барлыкка килмәү, тумасыз булу. *Бурлы бия быел кысыр калды.* Г. Ибраһимов. **Кысыр орлык** — шытмый торган орлык, аталанмаган орлык.

◇ **Кысыр кайгы (көек, хәсрәт)** — бер дә юкка (бушка) кайгыру, борчылу. [*Юматша:*] *Кысыр хәсрәттән башыңны кайгыга салма.* Г. Әпсәләмов. [*Гөлҗамал:*] *Юкны күреп үзеңне үзең ашап йөрисең икән. Ташла кысыр кайгыңны.* И. Салахов.

КЫСЫРЛЫК *и.* Кысыр калу, тума булмау (терлек турында). *Сыерларның кысырлыгын бетерү.*

КЫТАЙ *и.* **1.** Кытайда иң зур күпчелекне тәшкил итүче халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе. || *с. мәгъ.* Кытай халкына яки Кытайга караган, Кытайга яки кытай халкына мөнәсәбәтле. *Кытай теле. Кытай ефәге. Кытай фарфоры.* ▭ *Габдулла яхшы өйдә, яхшы самовардан чын кытай чәен дә җизнәләрендә бу кадәр ләззәт белән эчкән чагын хәтерләми.* Ә. Фәйзи.

2. Кайбер ботаник һәм зоологик терминнарның состав кисәге. *Кытай казы. Кытай киндере. Кытай чикләвеге.* ▭ *Агыйделләрнең буенда атып алдым кытай казларын.* Җыр. *Июньнән августка кадәр кытай канәфере чәчәк ата.* Йорт эшләре.

Кытай алмасы *бот.* — 1) алмасы бик вак булган, суыкка чыдамлы алмагач; 2) шул алмагачның җимеше. — *Кура җилгән зур таста кайнатырбыз, бусын --- кытай алмасына тотарбыз, диде.* Ә. Фәйзи. **Кытай карасы, кытай тушы** — махсус юл белән суда изеп ясалган буяу, тушь (күпчелек очракта кара була). *Рәсем астына шул ук чем-кара кытай тушы белән „1939" цифрлары язылган.* А. Шамов. **Кытай лимоннигы** *бот.* — магнолияләр семьялыгыннан, җимешләре дару ясауга китә торган үсемлек. *Чәй урынына кытай лимоннигын салып эчтеләр: бу эчемлек йончыган кешеләргә бераз хәл кертә иде.* И. Туктар. **Кытай розасы** *бот.* — бүлмәдә үстерелә торган мәң-

ге яшел, кызыл чәчәкле гөл. *Кытай розасы — мәңге яшел, күп таралган гөл.* Йорт эшләре.

◇ **Кытай стенасы** — нинди дә булса берәр күренешкә зур киртә, комачау булып торган нәрсә.

КЫТАЙЛЫ *и.* Кытайда яшәүче кеше.

КЫТАЙЧА *рәв.* Кытай телендә. *Кытайча сөйләшү.*

КЫТАКЛАУ *ф.* Кыска-кыска һәм өзек-өзек аваз-лар чыгару (тавык, әтәч турында). *Ата казлар каңгылдый, печәнлекләрдә, бөтен авылны шаулатып, тавыклар кытаклый.* Г. Бәширов. *Әтәч яткан җиренән кытакларга тотынды.* М. Гали.

КЫТАТ *и. иск.* Борынгы вакытта Кытайдан кертелә торган тыгыз ефәк тукыма. || Соңрак шундый төрдәге мамык тукыманы белдерү өчен дә кулланыла; китайка. *Анасы Казан байларының әлекке комач, кытат фабрикаларында эшләп гомер иткән.* Г. Ибраһимов.

КЫТКЫЛДАУ *ф.* 1. Кытаклау. *Шунда кыткылдый әтәч, мыркылдый шунда дуңгызы.* Г. Тукай. *Чуар тавык кыткылдый-кыткылдый күрше Шәвәлиләр янындагы койма астыннан чыгып килә.* А. Шамов.

2. *рәв. мәгъ.* **кыткылдап.** Шаркылдап, кычкырып (көлү турында). *Миңсылу да рәхәтләнеп кыткылдап көлеп җибәрде.* Ш. Камал.

◇ **Кыткылдап тору** — берәр нәрсә эшләргә, башкарырга бик теләп тору, әзер тору. *Гафурилар турында сорашырга йөрәк кыткылдап тора иде.* З. Бәширн.

КЫТКЫЛДЫК *с. сөйл.* Кыткылдый (1 мәгъ.) торган. *Әйтергә кирәк, минем Мияубикәм дә, кыткылдык тавыкларым да бер төстәләр.* Каз. утл.

КЫТ-КЫТ *аваз. ияр.* 1. *к.* кыт-кытыйк. —*Кыткыт,—ди бер әтәч,— тавыкларым, Килегез тиз, таптым борчак,— ди.* Б. Рәхмәт.

2. Кыткылдап көлү тавышын белдерә. *Рәхим әүвәл, кыт-кыт итеп, бик әч пошыргыч көлү белән көлә.* Ф. Әмирхан. *Үзе көлә кыт-кыт итеп, егылып төшә шап итеп.* Н. Исәнбәт.

КЫТ-КЫТЫЙК, КЫТ-КЫТЫЙ, КЫТ-КЫТАК *аваз ияр.* Тавык, әтәчнең кытаклау тавышын белдерә. *Бер заман сезнең бер чуар тавыгыгыз, „кыт-кытыйк, кыт-кытыйк" дип, сарык фермасыннан килеп чыкты.* А. Әхмәт. [*Тавык:*] *Кыт-кытак, кыт-кытак, сындырып бирче бер ботак.* А. Алиш.

◇ **Кыт-кытый күз** *гади с.* — *к.* тавык күз. [*Хәлим:*] *Миндә кыт-кытый күз, егетләр.* И. Гази.

КЫТЛЫК *и.* 1. Икмәкнең һәм азык-төлекнең булмавы яки бик нык җитмәве. *Аннан кытлык килде. Бабай ачлыктан шешенеп үлде.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Уңыш булмаган; азык-төлек һәм икмәк бик аз булган. [*Паларусов белән Фәхри*] *теге авыр, кытлык елларда бергә эшләделәр.* Г. Ибраһимов.

2. Кемгә яки нәрсәгә булса да чиктән тыш мохтаҗлык. *Китап кытлыгы.* □ *Көктугай халкы әлегә су кытлыгы күрмәде.* Н. Фәттах. [*Якуб:*] *Ышна җире — безнең үз җиребез. Аннары ул бик аз: җир кытлыгын бетерә алмый ул.* И. Гази. *Егетләргә кытлык түгел, Син килмәсәң бүтән бар.* З. Мансур.

КЫТНАУ *ф. диал. к.* кытаклау.

КЫТМЫЛДАП *рәв. иск. диал.* Аңсыздан, кинәттән.

КЫТЫЙ-КЫТЫЙ *и. к.* кети-кети. *Кытый-кытый уйнау.*

КЫТЫК *и.* Тәнгә җиңелчә генә тиюдән, орынудан кеше яки хайван нервысының тәэсирләнүе, ярсуы. *Врачлар группасы кешеләрнең кытыкка реакция ясауларын күзәткән.* Соц. Тат.

Кытык килү — *к.* кытыклану. — *Кытыгы килгәнгә чыдый алмыйча ул мине кире куйды.* М. Гали. *Тайның гомерендә беренче тапкыр тәртә арасына керүе булганга, кытыгы килә ахры.* С. Рафиков.

КЫТЫКЛАНДЫРУ *ф.* 1. Кытыгын китерү, кытыклау. *Салихның куе мыегы Хәятның йөзен дә, борынын да, маңгаен да кытыкландырыр.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Тәэсирләндерү; тынычсызландыру, җилкендерү, хисләр уяту. *Яшел сахралар караган саен күзләрне ягымлы гына тибрәтәләр, күңелне нечкә генә кытыкландырган хәлдә, табигатьнең чиксез-кырыйсыз матурлыкларына тартып ашкындыралар.* Ш. Камал.

КЫТЫКЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* кытыклау.

2. Кытык килү. *Сыртына адәм атланганын сизү белән, ыргытып бәрү өченме яки өйрәнмәгән тәннең кытыклануыннанмы, --- айгыр --- үрә сикерә, дулый башлады.* Г. Ибраһимов. || Кымыршжу, кымыршжып тору (тамак турында). [*Зарифның*] *тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланган шикелле булды.* Ә. Еники.

3. *күч.* Тәэсирләнү, тынычсызлану; җилкенү, нинди дә булса бер хис кузгалу. *Сөйләргә кытыкланып тору.* □ *Айсылу аның әрсезлегенә кытыклана башлаган иде.* Г. Бәширов. [*Миңлегали:*] *Шул арада аргамак җаныем абзарында пошкырып куя, йөрәкләр, тиздән кавышуны сизгәнгә, кытыкланып китә, сулыш кысыла башлый.* К. Тинчурин.

КЫТЫКЛАУ *ф.* 1. Тәнгә җиңелчә тиеп, орынып, нервларны тәэсирләндерү; кытык китерү. [*Галиулла*], *малайны кочаклап алып, мыек кыллары белән аның битен, муенын кытыклады.* И. Гази. *Газинур аяклары янына килеп иркәләнә башлаган Сарбайның колак артларын кытыклап алды да көлеп җавап бирде.* Г. Әпсәләмов. || Кымыршжыту, кымыршжу барлыкка китерү. *Төрле ашамлыклар күзне кызыктырып, тамак төбен кытыклап торалар иде.* М. Гафури. *Гажәп таныш ис аның борынын кытыклады: пешкән карта* [*карта*] *исе!* Ә. Фәйзи.

2. *күч.* (Күңелне, йөрәкне) тәэсирләндерү, җилкендерү, җиңелчә генә ярсыту; хис уяту. *Җырлаган тавыш боларның күңелләрен тагын кытыклап җибәрде.* М. Гафури.

КЫТЫКЧАН *с.* Кытыгы бик тиз килә торган. [*Хәйретдин:*] *Мин бик кытыкчан шул.* Ш. Камал.

КЫТЫ-МЫТЫ *җый. и. сөйл.* 1. Вак-төяк ашамлык. *Кунак җыйган көннәрдә безгә дә майлы бәлеш төпләре, кыты-мытылар күп әлгә.* Каз. утл. *Бар чагында — бал да май, юк чагында — кыты да мыты.* Мәкаль.

2. *диал.* Тормышның очын очка авырлык белән ялгап алып бару турында.

◇ **Кыты-мыты итү** — сәүдә итү, сату итү; спекуляция белән шөгыльләнү. [*Кәнҗебикә:*] *Синнән яшерен-батырын түгел инде, мин кала белән авыл арасында кыты-мыты итәргә керештем.* Т. Гыйззәт.

КЫТЫР *и. сөйл.* Нинди дә булса тигез предмет өстендә булган вак кына чыгынты, төерчек. *Катыргыдагы кытырлар.*

КЫТЫРДАУ *ф.* Кытыр-кытыр килү, кытыр-кытыр авазларына охшаган тавыш чыгару. *Күзне генә йомасың, кровать каршындагы комод тартмасында күсе кытырдый. Шикәрне көл итә. Булкины кимерә.* Г. Тукай.

КЫТЫР(Т)-КЫТЫР(Т) *аваз. ияр.* Нинди дә булса бер өслеккә орынганда, каты ашамлыкны кимергәндә яки чәйнәп ашаган вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Битюгның кытырт-кытырт ашавы ишетелеп тора.* И. Гази. *Койма буенда кытыр-кытыр үлән чүплән, Зөләйха апа янына бер ат килеп туктады.* Г. Мөхәммәтшин.

КЫТЫРЛАНУ *ф. сөйл.* Кытырлар барлыкка килү, кытыршылану. *Тәннәре ярылып беткән, кытырланган.* Н. Думави.

КЫТЫРЛЫ *с. сөйл.* Кытырлары булган. *Кытырлы пыяла. Кытырлы күн.*

КЫТЫРШЫ *с.* 1. Төерчекләре, кытырлары булган. *Сыерның берсе [Рәүфәне] йомшак кына мөңгерәп каршылады һәм, яратып, кытыршы теле белән аның кулын ялап алды.* А. Шамов. || Яргаланган; шома түгел. *Зәйнәпбану кышын-җәен өзлексез тирли торган калку кызыл маңгаен кытыршы куллары белән сыпырды.* Г. Бәширов. *Чынлап та, байларның алдында ат башы чаклы кызгылт һәм кытыршы бер таш.* М. Гафури. || *и. мәгъ.* Төерчек, кытыр. *Мәдинәнең уч эчендә бераз кытыршылар барлык сизелә һәм шушы кытыршылар аркылы Фәтхинең йөрәгенә ягымлы һәм матур мәгънәле җылылык агып торган төсле тоела.* Ш. Камал.

2. *күч.* Нинди дә булса кимчелекләре булган; кимчелекле (язу, стиль, тел турында). *Шәяхмәт үзенең кытыршы теле белән, русча вата-сындыра, Фәхринең язмышын сөйләп китте.* Г. Ибраһимов. *Тел ягыннан кытыршы җырлар да очрыйлар.* М. Җәлил.

КЫТЫРШЫЛАНУ *ф.* Кытыршыга әйләнү, кытыршы хәлгә килү. *Куллар кытыршылану.*

КЫТЫРШЫЛЫК *и.* 1. Кытыршы булу, кытырлар булу. *Кулның кытыршылыгы.*

2. *күч.* Кимчелек, җитешсезлек (телдә, стильдә һ. б.). *Шигырьне күргәч тә, сез аны такмаклап укырга керешерсез дә, анда бик күп кытыршылыклар табарсыз.* Һ. Такташ.

КЫХ, КЫХХ *аваз. ияр.* 1. Терлекне, кош-кортны суйганда барлыкка килә торган тавышны белдерә. || *хәб. функ. сөйл.* Сую, чалу. — *Әти, бер әтәчне кыхх!.. — диде Гали бармагы белән муенын сызып.* Р. Төхфәтуллин.

2. Какыру тавышын белдерә. *Мохитем булмады җанга көфү [тиң], шуның өчен дөньяга миннән [бүләк]: кых, тфү!* Ш. Бабич.

◇ **Кых итү** *сөйл.* — 1) сую, чалу. [*Котдус:*] *Анасы, пычак әзерлә, бу [әтәчне] кых итәм.* С. Рафиков; 2) *сөйл.* балалар телендә: кисү, кисеп кан чыгару. *Кулыңны кых итмә.*

КЫХ-КЫХ, КЫХЫК-КЫХЫК *аваз ияр.* Ютәллә тавышын белдерә. *Яз кояшы белән имтихан ясап, балаларны таратасың да, үзең кых-кых ютәллән, тагы авылга китәсең.* Г. Ибраһимов. *Муса, тончыгып, кыхык-кыхык йөткерә башлады.* Ш. Маннур.

КЫХЫМ *аваз ияр. к.* кыһым. [*Гөлбану:*] *Әһем, кыхым! Кара син аны, нинди белмәмешкә салынган булып маташа бит.* Г. Камал.

КЫЧКЫРТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* кычкыру (1, 4 мәгъ.). [*Десятник*] *аннан соң әтәчне кычкыртып, сул канатындагы йоннарын берәм-берәм йолкып чыкты.* М. Гали.

2. Махсус җайланма ярдәмендә авазлар чыгарып, нинди дә булса сигнал бирү. *Шул чакта ераста, бик ераста пароход кычкыртты.* Г. Гобәй. *Берничә паровоз, әче тавыш белән кычкыртып, үзләренә юл сорыйлар иде.* Ш. Усманов. || Нинди дә булса инструментта (мәсәлән, быргыда, сыбызгыда) уйнап, авазлар барлыкка китерү. *Сыбызгы кычкыртү.* □ *Әнә нинди-дер бер көтүче садә генә быргысын кычкырта.* Ф. Әмирхан.

3. *сөйл. кимс.* Уйнау (күбрәк гармоньда). — *Тәүфыйксызлар җыелып, гел эштән чыккан адәмнәргә генә ярый торган эшләр эшлилә р — гармонь кычкыртамы, бииме, җырлашамы... тагын шундый җыен ярамаган нәрсәләр.* Г. Ибраһимов.

4. *рәв. мәгъ. күч.* **кычкыртып.** Мәҗбүр итеп, көчләп, бернәрсәгә карамыйча. *Җил кайчакта, азгын юлчы төсле, Арышларны үбә кычкыртып.* М. Җәлил.

КЫЧКЫРТТЫРЫП *рәв. мәгъ. күч. к.* кычкыртып (кычкырту 4). *Сөннәтләргә кирәк булгач, кычкыртттырып сөннәтләгәннәр.* Һ. Такташ.

КЫЧКЫРУ *ф.* 1. Бик көчле аваз бирү, каты яңгыравыклы тавыш чыгару (кешеләр турында). *Халык кем кычкырганын тикшереп тормады.* М. Гафури. || Көчле авазлар чыгару (сыер, кәҗә, сарык һ. б. турында). *Өйгә ашкынган сыерлар, муеннарын сузып, берсеннән-берсе уздырып кычкыралар.* А. Шамов.

2. *к.* кычкырту 2. *Вокзал ягыннан батыр тавыш белән сузып-сузып паровоз кычкырган тавышлар ишетелә.* Ш. Камал.

3. Көчле тавыш белән бик нык ишетелерлек итеп әйтү яки сөйләү. *„Хуш, Миңнурый, сау булыгыз, туган җирләрем!" — дип, соңгы мәртәбә кычкыра Газинур.* Г. Әпсәләмов. *Бер солдат, бу итекне алам дип, кесәсенә акча алырга тыгылган гына иде, шул арада бер яктан икенче солдат кычкыра: „Тукта, әй, тукта, артык 10 тиен кушам, бир миңа итеңне".* Г. Тукай. || Көчле яңгыравыклы тавыш белән кемне дә булса чакыру. [*Гөлсем апа*], *әүтән җавап булмагач, тирә-якка карана-карана кычкырырга, ярдәмгә кешеләр чакырырга тотынды.* Г. Гобәй.

4. *сөйл.* Кемне дә булса яңгыравыклы каты тавыш белән әрләү, тиргәү. [*Асрау:*] *Кычкырырга беләсез, әскә-башка ясарга белмисез, менә алъяпкычларым тузып беткән, кычкырганчы бер алъяпкыч алып бир.* Г. Камал. [*Фатыйма*] *моңа теш-тырнагы белән каршы торачак: ачуланачак, кычкырачак.* И. Гази.

5. *сөйл.* Нәрсәгә дә булса игътибарны җәлеп итү өчен күп сөйләү, чыгышлар ясау. — [*Фазыл*] *да калышмаска тырыша бугай, әллә нинди оешмалар корып, --- лаф ора, шулай дип гәҗит яза, съездларда кычкыра.* Г. Ибраһимов. *Солых теләсәң, сугышка хәзер бул! Бу сүзне буржуазиянең идеологлары һәр чакта кычкыралар иде.* Ф. Әмирхан.

6. *рәв. мәгъ.* **кычкырып.** Яңгыратып, көчле тавыш белән. *Кычкырып көлү.* □ *Болай да суыкка катып, өшеп кергән малай бөтенләй эштән чыкты, кычкырып еларга да тотынды.* М. Гали. *Камил, телеграмманы алып, кычкырып укый.* Һ. Такташ.

◇ **Кычкырып торган** — 1) күзгә бәрелеп торган, үзенең бик чуар яки җете булуы белән игътибарны тарта торган; 2) ачык беленеп (сизелеп) торган, ачык. [*Аяз:*] *Мин фәлән кеше булам дип үзеңне дәртләндереп, җилкендереп торган берәр төпле ниятең булса икән. Кычкырып торган бер омтылышың!* Г. Бәширов.

КЫЧКЫРЫК *и.* 1. Бүленеп-бүленеп ишетелгән яңгыравыклы тавыш, аваз. *Төрле тавыштан гаҗәепле бер матур гөрелте чыга: әллә кайларда чылтырап аккан елга тавышлары, --- бишек тирбәткән көйләр, әллә кайда ишетелгән көтүче кычкырыклары.* Ш. Камал.

2. *лингв.* Борынгы кеше берәр төрле предметның тавышына охшатып яисә берәр предметны күргәч тә, имештер, әйткән һәм оешмаган дип саналган авазлар (телләрне ымлыклардан килеп чыга дигән караш буенча). *Кешеләр көчле әсәрләнү, тойгылану, көчәнү кебек хәлләрдә авызларыннан ирексез һәртөрле авазлар чыгаралар. Менә шушы тойгылы кычкырыклар, ымлыклар бара-бара мәгънәле сүзгә әйләнеп киткәннәр, телдәге сүзләр шуннан таралган дип карала.* Г. Алпаров.

КЫЧКЫРЫҢУ *ф.* 1. Кычкыра-кычкыра әйтү яки сөйләү. — *Менә күрешик әле, һәммәсен сөйләрмен,*

ысул җәдитчеләрнең бөтен серләрен чишәрмен,—дип кычкырына-кычкырына теге татарның янына барып җитте. Ф. Әмирхан.

2. Кычкырып тиргәү, кычкырып әрләү. *Шулай инде аның әнкәсе: башта кычкырынды, җикеренде, ә менә хәзер эзли чыккан.* И. Гази.

КЫЧКЫРЫШ *и.* 1. Кычкырган тавышлар, кычкырган авазлар. *Чыр-чу, тавыш, кычкырыш купты: „Ут баррр!!! Янабыз! Пожар!!“ — дигән йөрәккә төшә торган ачы, ямьсез тавышлар минуты белән бөтен авылны чолгап алдылар.* М. Гали.

2. Кычкырып тиргәшү, әрләшү, талаш. [*Себер бае:*] *Җәмгыятегезгә барсаң, анда талаш, клубыгызга барсаң, анда кычкырыш, ресторанга керсәң, анда җәнҗал!* Г. Камал. || Кычкырып тиргәшкән тавышлар, кычкырып шелтәләгән тавышлар. *Бөтен бүлмәләрдән, коридордан, залдан бөтен дөньяны җимергән сыман бер каты шау-шу, гауга, талаш, кычкырыш күтәрелә.* Г. Ибраһимов.

КЫЧКЫРЫШ-ТАЛАШ *и. к.* талаш-кычкырыш. [*Пьесада*] *җәдитчеләр тарафыннан оештырылган клуб күренешендә дә иң зур культура эше булып лото, домино уйнау күрсәтелә. Ул да зур кычкырыш-талаш һәм тәртипсезлекләр белән бара.* М. Гали.

КЫЧКЫРЫШУ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* кычкыру (1, 3 мәгъ.). *Җыелган халык, уен-көлке белән кычкырышып, шатланышып, шаярышып, атларны тугара, чанадагы әйберләрне бушата калдылар.* Г. Ибраһимов.

2. Кем белән дә булса үзара кычкырып тиргәшү, талашу, кычкырып әрләшү. [*Сафа*], *уянып бераз тын ятканнан соң, урынныннан торды, аяк очлары белән генә басып, ишек төбенә барды һәм атасы белән анасының кычкырышканын тыңларга кереште.* А. Шамов.

КЫЧУ I *и.* Кеше яки хайванның тиресенә кычу бете үтеп керүдән барлыкка килгән йогышлы тире авыруы (бу вакытта тиредә вак-вак сусыл төерчекләр барлыкка килә һәм тире бик нык кычыта). *Кычу азса — корчаңгы.* Мәкаль.

Кычу үләне *бот.* — чәчәге мамык сыман төк бирә торган озын үлән үсемлек; *русчасы:* ворсянка.

КЫЧУ II *ф. сөйл. к.* кычыту. *Эшсезнең кулы кычыр.* Мәкаль. [*Вәли карт:*] *Кай җирең кычый! Эттән алып эткә салып ташлады үземне.* Ш. Камал.

КЫЧУЛАУ *ф.* Кычу чыгу, кычу басу.

КЫЧЫНУ *ф. сөйл.* 1. Тән кычыту, тәндә кычыту тою. —*Менә шуннан соң парлы мунчага кереп, кычынуларың басылганчы яшь каен себеркесе белән чабынсаң, дөнья түгәрәкләнә инде.* М. Гали.

2. *күч. гади с.* Нинди дә булса бер эшне эшләргә бик нык теләү, омтылу. [*Гыйсми:*] *Мулла налогын түләргә кычынып торасыз... Әйтерсең үзенең хәле җитми аның.* А. Шамов.

КЫЧЫТКАН *и.* Яфракларында һәм сабагында тәнне чага торган төкләре булган үсемлек. *Кычыткан чагу.* □ *Урамнар алабута, кычыткан һәм башка үләннәр белән тулы.* М. Гафури. *Чормасына төрле дару үсемлекләре: бәйләм-бәйләм ак әрем, юкә чәчәге, үги ана яфрагы, мәтрүшкә, ак чәчәк, яшь кычыткан һәм сирень чәчәкләре кибәргә эленеп куелган.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Кычытканнан хәзерләнгән, кычыткан салып пешерелгән. *Балаларны, кузгалак һәм кычыткан ашы, юкә яфрагы һәм әлмә кайрысы белән тамакларын туйдырып, үлемнән алып калучы да - - - Айсылу үзе иде.* Г. Бәширов. || *с. мәгъ. күч.* Тупас киндер тукымадан тегелгән. *Хатын арбасындагы печән астыннан ике зур-зур кычыткан капчыгы чыгарды.* А. Гыйләҗев.

Кычыткан бизгәге *мед.* — кычыткан чаккандагы кебек, төрле кычытып торучы таплар бер чыга, бер бетә торган авыру; бүре уы. **Кычыткан гөл** *бот. диал.* — үзенең формасы белән беркадәр кычытканга охшаган бүлмә гөле, әдрәс гөл; *русчасы:* колеус. **Кычыткан ефәге** *бот.* — кычыткан сабагына уралып үсә һәм аннан тукландыргыч матдәләр ала торган яфраксыз һәм тамырсыз паразит үсемлек. **Кычыткан кынасы** *бот.* — *к.* кычыткан ефәге. **Кычыткан күбәләге** *зоол.* — кортлары кычытканда яши торган чуар күбәләк. **Кычыткан чыпчыгы** — 1) *зоол.* урманда яши һәм кычыткан орлыгы белән туклана торган соры-көрән төстәге кечкенә сайрар кош. [*Ул*] *кычыткан чыпчыгының тыйнаксыз балалар кебек бер урында тыныч кына тора алмавын, гел сикергәләп очып йөрүен искә ал*[*ды*]. Г. Галиев; 2) *күч. сөйл.* теләсә нинди сүзгә, эшкә кысылырга яратучы, тиктормас кеше турында. *Теге Миләүшә атлы кычыткан чыпчыгы турында да кайбер биографияләрне белеп алдым.* Ф. Хөсни.

◇ **Кычыткан тел** — усал, зәһәр телле кеше турында. *„Нинди кешелекле адәм бу Миңлекәев абый, ә кычыткан тел Гыйззелбанат аның турында әнә ни сөйли“, — дип уйлап алды Маһруй.* Г. Әпсәләмов.

КЫЧЫТКАНЛЫК *и.* Кычытканнар үскән урын, күпләп үсеп утырган кычытканнар. *Мин, ертык күлмәк-ыштан аркылы ялангач тәнемне кычыткаңнан чактырмыйм дип, сакланып кына кычыткаңлыкка кереп постым.* Ә. Айдар.

КЫЧЫТКЫ *и. сөйл. к.* кычу I.

КЫЧЫТТЫРУ *ф.* Тәндә кычыту барлыкка китерү, кымыржыту.

КЫЧЫТУ *ф.* Тәндә кашыйсы килү хәле тою. [*Гарифның*] *яңагындагы җәрәхәт күңелен борчымый, бәлки ләззәтле сымак әрнеп кычыта гына иде.* Ш. Камал. *Менә мунча да салып җибәрергә уйлап йөри: арка кычыткан саен кешегә мунча сорап керүе уңайсыз.* И. Гази. || Кымыржу, кымыржыту (тамак турында). *Тамак кычыту.*

◇ **Кычытмаган урынны (җирне) кашу** — кирәкмәгән эш эшләү; буш, тиешсез эш белән шөгыльләнү; бушка сөйләшү. [*Закир:*] *Бу озын сакал Селиваныч, кычытмаган урынны кашып йөргәнче, рәтлерәк күсәк куйса, файдасы тияр иде.* Ф. Сәйфи-Казаңлы. [*Ризванов:*] *Кычытмаган җиреңне кашырга ашыкма.* Ф. Хөсни.

КЫШ *и.* Елның дүрт фасылыннан берсе, көз белән яз арасы, елның иң салкын вакыты. *Кыш, буран, салкын һава, яфрак кадәрле кар төшә.* Г. Тукай. *Көз артыннан кыш дигән һәм бер нәрсә бар, Ялбыр-йолбыр ява башлар шул вакыт кар.* М. Гафури. || Кышкы салкын, суык. *Кыш, урамга чыккан кешеләрнең борынын кызартып, кызык итә.* Һ. Такташ. || *с. мәгъ.* Кышка бәйләнешле, кышка караган, кышкы. *Дөрес, өй инде искесен иске, кыш көннәрендә аның чатларына бәсләр дә керә.* А. Шамов.

Кышка чыдамлы — кышкы салкыннарга һәм кыш көне була торган башка авыр шартларга бирешми торган (үсемлек, агач һ. б. ш. турында). [*Боровинка*] *кышка бик чыдамлы һәм авыруларга каршы түземле, ләкин алмалары еш кына кутырлыйлар.* Жилөкжимеш... **Кыш чыгу** — кышны үткәрү, кышлау. [*Нургали:*] *Болынлык аз, печән кыш чыгарга җитми, бәрәңге, тамыразык мәйданын арттыруны идарә алдына куярга!* Ә. Еники. **Кышка керү** — кыш шартларында яши башлау. *Умарта корты җәй көненда чәчкәләрдән бал җыя; Кышка керсә, кыш буенча умартасында хәл җыя.* М. Гафури. **Кыш көне** — кышкы шартларда, кыш вакытында, кышын. [*Нәфисә:*] *Кыш*

көне кар тоттык, яз көне тагын килеп кар сулары буып йөрдек. Г. Бәширов.

◇ **Кыш бабай** — 1) кышны, кышкы суыкны белдерә. [*Балалар урамга*] *чыгарлар иде шул, кыш бабай бик яман куыра, брезент чүәкләр белән бик тиз өйгә куып кертә.* А. Алиш; 2) кышның, кышкы суыкның символы; җылы тун һәм бүрек кигән, ак сакаллы һәм мыеклы карт рәвешендәге фантастик зат. [*Әтисе*] *аларның икесенә дә шундый ук бизәкле, шундый ук чыршы һәм кыш бабай сурәте төшерелгән билет алып кайткан иде.* А. Шамов. **Кыш көне кар бирмәс** — бик саран кеше турында. **Кыш салкыны** — салкын мөнәсәбәт, салкын караш. *Карчыкның чырае җансыз, күз карашыннан кыш салкыны бәреп тора иде.* Сов. әд. **Кыш(ның) бавыры** — кыш вакыты, кыш дәвамы. — *Кыш бавыры бик озын, нигә ягарыңа бик аз әзерлисең?* Г. Бәширов. **Кыш(ның) корсагы зур гади** *с.* — кышын азык-төлеккә, утынга һ. б. ш. киләк-яракка ихтыяҗ зур булуга ишарә.

КЫШКЫ *с.* 1. Кышка бәйләнешле, кышка караган, кыш көнендә булган. *Кышкы юл.* □ *Кышкы салкын буранда да, Хат ташып йөргәндә дә, Я укырга, я уйнарга Клубка килгәндә дә Мин гел сине уйлый идем.* М. Җәлил. *Кышкы төннең салкын күкрәгеннән Чаналар да шаулап үттеләр.* Һ. Такташ.

2. Җимеше соң өлгерә һәм озак вакыт бозылмый саклана торган (җимеш агачлары турында). *Алмалары озак вакыт саклау өчен яраклы кышкы сортлар: антоновка, әнис, пепин, славянка.* Җиләк-җимеш...

3. Кыш өчен билгеләнгән, кыш көне кулланыла, файдаланыла торган. *Кышкы аяк киеме.* □ [*Мәйпәрвәз ханым:*] *Кышкы пальтоңның якасы кыршылган түгелме соң?* Ә. Еники.

Кышкы йокы — 1) кыш көне, тереклек эшчәнлеге бик нык кимеп, кайбер имезүчеләрнең йокыга талу халәте. *Кышкы йокысыннан уятылган ана аю кебек тузгыды ул.* Г. Гобәй; 2) кыш көне табигать эшчәнлегенең гомумән сүрәнләнүе турында. *Агач яфрагын коя да кышкы йокысына тала.* Г. Бәширов. **Кышкы кояш торгынлыгы** *астр.* — көннең иң кыска вакыты (21 — 22 декабрь). **Кышкы челлә** — кышын булатторган иң салкын вакыт (25 декабрьдан 5 февральгә кадәр). *Кышкы челләнең --- каты буранлы, салкын җилле караңгы төннәренең берсе иде.* Г. Ибраһимов.

КЫШЛАВЫК *и.* Кышлый торган урын; кыш яши торган өй.

КЫШЛАК *и.* Урта Азиядәге торак пункт, авыл. [*Сөләйман:*] *Кыш укыр өчен җәйләрдә утын кистем, сал чыгардым, йон юдым, Мәкәрҗәдә половой булдым. Төркстан кышлакларыннан, татар дип, патша полициясеннән сөрелдем.* Г. Ибраһимов.

КЫШЛАУ I 1. *ф.* Кышны үткәрү, кышны уздыру; кыш чыгу. *Ул кышны* [*безнең гаскәрләр*] *Карпат таулары арасында, Станислав тирәләрендә һәм Венгрия чикләрендә кышладылар.* М. Гали. *Яфраклар коелып беткәч, кошлар җылы якка киткәч, бал кортларының ояларын җылы урынга кышларга күчерделәр.* А. Алиш.

2. *и.* Кышны үткәрә торган, кышын яши торган урын. [*Казакълар*] *күптән инде, ак тирмәләрне төяп, яшел сахра белән исәнләштеләр, яртылай җир астына кергән җимерек балчык кышлауларына кайттылар.* Г. Ибраһимов. *Һаваларда очкан аккошның Агыйделдә булыр кышлавы.* Җыр.

Кышлау умарта — 1) кышларга тышта калдырылган бүрәнә умарта; 2) *күч. сөйл.* бик юан кеше, аерым алганда, хатын-кыз турында. **Кышлау өе** — бал кортлары яшәгән умарталарны кыш көне саклый торган бина. *Әгәр кышлау өендә салкын һәм тынчу булса, кортлар катырак гөжлиләр.* Җиләк-җимеш...

КЫШЛАУ II *с.* Туганнан соң бер кыш кышлаган (терлек турында). *Безнең кышлау тәкәне кертмибез. Әниләр күрмәгәндә, чыбык белән сыптырып, югары очка куып җибәрәбез.* Г. Мөхәммәтшин.

КЫШЛЫЙ *рәв. сөйл. к.* кышын. [*Бәдри:*] *Анда --- кышлый мондагы кебек кар яумый — җылы, рәхәт.* И. Гази.

КЫШЛЫК *с.* Кышын кулланыла торган; кыш өчен билгеләнгән; кыш чыгарга җитәрлек. *Кышлык азык.* □ *Монысы дала халкының кышлык утыны иде.* Н. Фәттах. *Аның шактый әре башында арзанлы бәйләгән бүрек белән өстендәге иске генә кышлык пальто да ничектер килешле күренә иде.* Ш. Камал. || *и. мәгъ.* Кышны үткәрү өчен билгеләнгән азык. *Байгузиннар уникә каз, бер тана, бер илләмсез зур дуңгыз һәм, өч хуҗа берләшеп, бер яшь ат суйдылар. Дуңгызы — сатар өчен, ә калганнары үзләренә кышлык өчен иде.* Ә. Еники. *Бу көн ашарыма бар дип, хафасыз бушка йөрмиләр, Җылы көн, кулда форсат бар вакыт кышлык әзерлиләр.* М. Гафури.

◇ **Кышлыгы юк** — кыш көне тиз туңа, тиз өши торган кеше турында.

КЫШЛЫККА *рәв.* Кышны уздыру өчен, кыш чыгу өчен. [*Гарәфи абзый*], *мин киткәч, өйдәгеләргә кыен булмасын дип, кышлыкка утынын кисеп-ярып, әрдәнәгә өеп куйды.* Г. Әпсәләмов. *Беркөнне умартачы бабай белән әлеге малай умарталарны кышлыкка хәзерләп йөриләр иде.* А. Алиш.

КЫШЛЫКСЫЗЛАНУ *ф. сөйл.* Кышны авыр үткәрә торганга әйләнү, суык көннәрне үткәрә алмый торганга әйләнү. — *Әйдә, урам күрик. Өйдә ятып кышлыксызлануың бар.* М. Хәсәнов.

КЫШТЫРДАВЫК *с. к.* кыштырдавыклы. *Кыштырдавык кәгазь.*

КЫШТЫРДАВЫКЛЫ *с.* Кыштырдап торган, кыштыр-кыштыр килеп торган. *Ялтырап торган кыштырдавыклы каты кәгазьгә, йомшак кына тел белән, --- Зиннәтне, кызганычка каршы, музыка мәктәбенә кабул итә алмаулары турында язганнар иде.* Г. Бәширов.

КЫШТЫРДАНУ *ф. сөйл. к.* кыштырдау.

КЫШТЫРДАТУ *ф.* Нәрсәне дә булса кыштыр-кыштыр китерү; кыштырдау тавышы барлыкка китерү. [*Гыйльманов*], *каләмен тагын да йөгерекләндерә төшеп, кәгазьне тагын да шәфкатьсезрәк кыштырдатырга кереште.* Ш. Камал. *Көймә очлы күкрәге белән вак ташлы комны кыштырдатып килеп ярга бәрелүгә, Марат та, Илдар кебек үк, куанып әтисенә сарылды.* Г. Гобәй. || Кыштыр-кыштыр чәйнәү (саламны, печәнне һ. б. ш. — күбрәк хайваннар турында). *Мин бабайның чабатасын тезеп утырам, кырыкмыш яткан җиреннән печән кыштырдатып ята.* М. Гали.

КЫШТЫРДАУ *ф.* 1. Печән, салам кебек әйберләргә кагылып, өзек-өзек җиңелчә тавыш барлыкка китерү; кыштыр-кыштыр килгән тавыш чыгару. *Кыштырдаган тавыш.* □ *Менә кыз, ниндидер кыштырдау ишетеп, сискәнеп, Сафа яткан урынга таба кинәт борылып карады.* А. Шамов.

2. *күч.* Әкрен генә, ашыкмыйча гына берәр эш эшләп маташу. *Каралтымда — бары үлгән кебек, Кыштырдаган ярты җан да юк.* Ш. Маннур. — *Бер көе генә кыштырдап йөрим шунда.* М. Фәйзи.

Кыштырдап торган — яңа, таушалмаган (кәгазь, акча һ. б. ш.). *Күн киемле кеше башын чайкап куйды һәм куен кесәсеннән кыштырдап торган бер кәгазь алып Сәлимгә сузды.* Г. Гобәй.

КЫШТЫРДЫК *с.* Кыштырдап торган, кыштырдый торган. *Менә кыштырдык плащ тагын лап-лоп бирегә якынлаша.* Р. Төхфәтуллин.

КЫШТЫР(Т)-КЫШТЫР(Т) *аваз иярт.* Бер нәрсәнең икенче нәрсәгә орынуыннан, ышкылуыннан, коры үлән сабаклары бер-берсенә тиюдән, нәрсә булса да сынудан яки нинди дә булса хәрәкәттән барлыкка килгән өзек-өзек җиңелчә саңгырау тавышны белдерә. *Кыштыр-кыштыр язу.* □ *Хәлим, учына төкереп, урагын бераз әйләндергәләп торды да, иелеп, кыштыр-кыштыр ура башлады.* И. Гази. *Эшчеләр, урыннарыннан торып, кыштыр-кыштыр киенеп, кереп-чыгып йөри башладылар.* М. Гафури. || Терлекләр салам, печән кебек азыкларны чәйнәгәндә чыккан тавышны белдерә. *Төяләрнең кыштыр-кыштыр әллә нәрсә чәйнәгәннәре ишетелә иде.* Г. Тукай. || Вак ташлар өстеннән барганда, аларга бәрелгәндә барлыкка килгән өзек-өзек саңгырау тавышны белдерә. *Менә шулай таза „ГАЗ-67" машинасы ташлы ком сипкән юлдан кыштыр-кыштыр чапкан чакта, ул аны гүя янәшәсендә тоеп бара иде.* Ә. Еники.

Кыштыр(т)-кыштыр(т) килү — кыштырдау. [*Хөббениса*], *кыштыр-кыштыр килеп, үзенең бетмәс-төкәнмәс эшләре белән маташып йөри.* Р. Төхфәтуллин. *Җиләс һава, кыштырт-кыштырт килеп, Кереп посты камышка.* Б. Рәхмәт.

КЫШТЫР-МЫШТЫР: кыштыр-мыштыр килү — ашыкмыйча гына кыймылдау, әкрен генә берәр нәрсә эшләү. *Маһибәдәр, - - - кыштыр-мыштыр килеп, ян бакчага чүп-чар утарга кереп китә.* А. Гыйләҗев. *Хөббениса карчык дәшми, әмма чыгып та китми, шунда кыштыр-мыштыр килеп йөри.* Р. Төхфәтуллин.

КЫШЫН *рәв.* Кышкы чорда, кыш көне. *Кышын кар күп булса, җәен иген уңа.* Мәкаль. *Кышын монда күз ачкысыз бураннар була, Идел өстендә кешеләр адашып йөри.* М. Гали.

КЫШЫН-ҖӘЕН *рәв.* Елның теләсә нинди вакытында, төрле табигать шартларында, һәрвакыт. *Зәйнәпбану кышын-җәен өзлексез тирли торган калку кызыл маңгаен кытыршы куллары белән сыпырды.* Г. Бәширов.

КЫЮ I *с.* 1. Курку хисенә бирелми торган, курыкмый торган; батыр, тәвәккәл. *Кыю партизаннар.* □ *Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә һәм үләргә кыю ир булып.* М. Җәлил. | *и. мәгъ. Кыюның бәхете алдан йөрер.* Мәкаль. *Рота командиры бу җаваплы операциядә катнашыр өчен кыюларның да кыюын, җитезләрнең дә җитезен генә сайлап исемлек төзеде.* А. Әхмәт. || *рәв. мәгъ.* Бер нәрсәдән дә курыкмыйча, батырларча. *Элек чыбык-чабыкка орынырга котлары алынып торган кешеләр хәзер алпавыт урманына үз бакчаларына кергән кебек кыю керәләр.* И. Гази. *Көрәштә чыныга, нигый барган Кызыл Армия торган саен дошман өстенә кыюрак һөҗүм итә.* Г. Гобәй.

2. Батырлыкны, тәвәккәллекне белдереп торган; батырлыкны, тәвәккәллекне күрсәтә торган. *Күрә алда Батырларның кыю йөзләрен.* Ф. Кәрим. [*Газинур*] *артына борылып карамады, ләкин командирның гына түгел, бөтен батальонның аңардан кыю хәрәкәт көткәнен сизенде.* Г. Әпсәләмов. || *рәв. мәгъ.* Кискен, кискен рәвештә. *Сабир абзыйга Сәйфулланың капчыкны төбеннән тотып селекмәве һәм шул ук вакытта өзеп кыю гына җавап бирүе ошый иде.* Ә. Еники. *Өй эченнән тавыш бирүче булмагач, бераздан соң ул кыюрак һәм катырак шакылдатты.* А. Шамов.

3. Кыенлыклардан курыкмый торган; яңага омтылучан. *Кыю яшьлек.* □ *Аның кыю чыгышларын Сөйгиләр бөтен илдә.* Ә. Исхак.

4. *рәв. мәгъ.* Тартынмыйча, уңайсызланмыйча; оялмыйча. *Хәзер исә аның [Зиннәтнең] үз эченә кысылып, сыкранып яткан әчке дөньясы тышка чыгарга омтыла, - - - ул беренче мәртәбә шулай кыю һәм иркен сөйләшә иде.* Г. Бәширов.

КЫЮ II *ф. гадәттә юкл. форм. кулланыла.* Батырчылык итү, кыюлык итү, базу. [*Габдулла:*] *Сөләйман әфәнде белән утырган вакытыгызда килеп борчырга кыймадым.* Ф. Әмирхан. *Курыкмадың, монда ничек кердең кыеп?* Г. Тукай.

КЫЮ III *ф.* Өстен кисү; кистереп алу. [*Хәлим*] *барып җитүгә арбасыннан сикереп төшә дә, апасының кычкыруына карамастан, урагы белән арыш башагын кыеп йөри.* И. Гази. *Су буенда кыяк үлән, Кыеп аласы иде.* Җыр. || Чабу, чабып алу, кыйгачлап кисү; ую, уеп алу. [*Садыйк*] *уңай җирен ышкылады, ышкы ала алмаган урыннарын үткен балта белән кыеп төшерде.* Г. Ибраһимов. *Борисов үткен пәкесе белән карандашны кыеп-кыеп төшерә.* А. Гыйләҗев.

◇ **Кыеп салу** — 1) кирәген бирү, тиешле отпор бирү. [*Комиссар:*] *Дошман агентын беренче сүзендә үк кыеп салырга кирәк.* Г. Бәширов; 2) күпләп үтерү (мәсәлән, сугышта дошманнарны).

КЫЮЛАНУ *ф.* Батырлану, батыраеп китү, кыюга әйләнү. [*Нәсимә:*] *Оялтма яшьләрне, безнең кебек берәр ай торгач, кыюланырлар әле.* Р. Ишморат. || Батырчылык итү, базу, кыю. *Малай, кыюланып, автомобиль басмасына менеп басты һәм кулын бургыга сузды.* А. Шамов.

КЫЮЛЫК *и.* 1. Кыю булу, батыр булу, батырлык; тәвәккәл булу. *Кыенлыкта күренә кыюлык.* Мәкаль. *Аның бу кыска җавабында, бигрәк тә акыллы күз карашында теләк тә, кыюлык һәм ниндидер зирәклек тә бар иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Кыю эш, кыю хәрәкәт, батырлык. *Без сүнсәк тә, безнең кыюлыктан Арта бары [илнең] яктысы.* М. Җәлил. *Махночылар, көтелмәгән бу кыюлыктан гажәпкә калып, кинәт туктадылар.* Г. Бәширов.

Кыюлык итү — батырчылык итү, тәвәккәллек итү; базу. [*Габдулла*] *магазиннарны ябып күю байларның үзләре өчен куркынычлы икәнлеген, алар моңа кыюлык итә алмаячакларын сөйләде.* Ш. Камал.

КЫЮСЫЗ *с.* Кыю булмаган, тәвәккәл булмаган; кыюлыгы җитмәгән; куркак. [*Сестра:*] *Ах, нинди кыюсыз егет син!* А. Шамов. || Кыюлык җитмәүне белдергән, куркуны белдергән. *Шәкерт күп җәфа кичергән яшь йөзе белән бераз тартына төшеп елмайды, кыюсызрак тавыш белән җавап бирде.* Г. Ибраһимов. || *рәв. мәгъ.* Куркып, шүрләп; тартынып, уңайсызланып. [*Бабай да, Зөһрә дә*] *икесе берьюлы кулларын кыюсыз гына кәгазьләргә суздылар.* Г. Гобәй. [*Бикбулат*], *бераз мышнап торганнан соң, кыюсыз гына: „Чын булып чыктымыни?" — диде.* Г. Бәширов. *Сажидә апа кыюсыз гына елмайды.* Ә. Еники.

КЫЮСЫЗЛАНУ *ф.* Кыюсызга әйләнү. || Курку, тартыну, уңайсызлану, базмау. *Шәкерт яшьләр башта бераз тартынып, кайберләре кыюсызланып торсалар да, тиз телләнделәр, бер-берсен бүлә-бүлә, идарә белән сүгешләрне сөйләргә керештеләр.* Г. Ибраһимов. *Сәлим, кыюсызланып кына, дүрт почмаклы өстәлнең бер читенә килеп утырды.* Г. Гобәй.

КЫЮСЫЗЛЫК. *и.* 1. Үз-үзеңә ышанмаудан килгән куркаклык. *Мостафин хәленә төшкән кеше өчен гадәттә икеләнү, кыюсызлык хас була.* Ә. Еники.

2. Тартынып тору, базмау, уңайсызлану турында. *Хәлим белән сестра да үзләренең кыюсызлыкларын оныталар, шаулыйлар, көлешәләр.* А. Шамов.

КЫЮЧЫЛЫК: кыючылык (итү) кылу — батырчылык итү, тәвәккәллек итү, базу. [*Бари:*] *Без сезгә турыдан-туры бүләк итеп бирергә кыючылык итә алмаган булыр идек.* М. Фәйзи. [*Чибәр егет*] *болай гына сине туктатырга кыючылык кылмас.* Ш. Камал.

КЫЯ *и.* Үтә текә таш тау; шундый тауның текә бите; үтә текә таш тауда чыгып тора торган зур таш. *Юл, барган саен, куркыныч җирләрдән үтә. Аста — тирән чокырлар, икенче якта — өскә аварга торган кыялар, ташлар.* М. Гафури. *Су буенда бер кыя бар, Ямьләп тора Иделне.* Ә. Ерикәй. || Кыя формасындагы нәрсә (күбрәк боз тавы турында). *Алга карыйм: бозлар кыясында Седов тора, алга кул сузган.* Ф. Кәрим.

Кыя тау — *к.* кыя. [*Җик*], *куркыныч якынлашканын сизеп, кыя тауга менеп баса да, тиз генә җәясен алып, Уразмәт белән сүз куешу буенча, көмеш угын һавага атып җибәрә.* М. Җәлил. **Кыя таш** — текә тауда чыгып тора торган зур таш. *Мин онытылып сиңа карап калдым, Баскан килеш кыя ташына.* Ш. Маннур.

КЫЯК *и.* 1. Суганда, сарымсакта, иген һәм үләннәрнең кайбер төрләрендә була торган озын тар яфрак. *Калмас* [*кәҗәдән*] *кәбестә, суган кыяклары.* Г. Тукай. *Сөмбелләрнең кыягында Таң чыклары мөлдери.* Ә. Ерикәй.

2. *сөйл. к.* кыяк үлән. [*Күлнең*] *тирәләре яшел кыяклар, шаулап торган камышлар белән капланган икән.* А. Алиш.

Кыяк гөл *бот.*— *к.* кыяклы гөл. **Кыяк суган** — кыяклары ашамлык итеп кулланыла торган суган. *Кыяк суган үстерү.* **Кыяк чыгару (җибәрү)** — кыяклану, кыяклар барлыкка килү (кыяклы үсемлекләрдә). *Суган тишелеп чыккач, рәт араларында туфракны көпшәкләндерәләр, ике-өч чын кыяк чыгаргач, чәчүлекләрне, 2—3 сантиметрда бер үсемлек калдырып, сирәкли.* Җиләк-җимеш... **Кыяк яру** — *к.* кыяк чыгару. **Кыяк үлән** *бот.* — кыяклылар семьялыгыннан терлек ашатуга китә торган күпьеллык чүп үлән; *русчасы:* осока. *Бу алан хәзер сарут, күзлут, алабута һәм саргайган кыяк үләннәр белән күмелеп калган.* А. Гыйләҗев. *Яр буенда кыяк үлән, кыеп аласы иде, Мәңге сагынмаслык итеп карап каласы иде.* Җыр.

◇ **Кыяк кебек** *диал.* — бик үткен (мәсәлән, пычак). **Кыяк тешләү** — бөлгән сәүдәгәрләрнең үзләре акча алган кешеләреннән качып йөрүләре турында. *Эшләр чуала башлагач, байлар кыяк тешлиләр.* Ш. Мөхәммәдев.

КЫЯКЛАНУ *ф.* Кыяклар җибәрү, кыяклар чыгару. [*Агроном:*] *Ә тарыгыз кыяклангач, тагы утарсыз.* Г. Гобәй. *Минем кызыл кәбестәм кыяклангач,--- Күршем беркөн базардан алып кайтты бер кәҗә.* М. Җәлил.

КЫЯКЛАУ *ф. сөйл.* Качу, качып китү. *Сәүбәннең шактый вакыт үзе белән бергә булып та, кырын килә башлагач, аны-моны уйлап тормыйча, бер җаен табып, кызыллар ягына кыяклавын язган иде.* Ф. Хөсни.

КЫЯКЛЫ *с.* 1. Кыяклары булган, кыяклар җибәрә торган. *Кыяклы үсемлекләр.* □ *Бер өлешләләр классына кыяклы ашлыклар (бодай, кукуруз, арыш, дөге, тимофеевка), кайбер яшелчә үсемлекләр (суган, сарымсак) керәләр.* Ботаника.

2. Кыяклар (2 мәгъ.) белән капланган, кыяклар үскән. *Саз эченда кыяклы түмгәк өстенә чыбык-чабыклар өеп, үрдәкләр оя ясаганнар.* А. Алиш.

3. *и. мәгъ. күпл.* **кыяклылар** *бот.* — тар озын яфраклы (кыяклы), сабаклары буынтыклы һәм эче куыш булган бер өлешле үсемлекләр семьялыгы. *Кыяклыларның барысы да диярлек — үләнчел үсемлекләр.* Ботаника.

Кыяклы гөл — ачык яшел яфраклы, озын сабаклы күпьеллык гөл; *русчасы:* драцена. *Тәрәзәдән кыяклы гөл аша карап тора төн.* Ф. Кәрим. **Кыяклы суган** — *к.* кыяк суган. *Кыяклы суган үстерү өчен сайлаудан калган вак суганнан яки башлы суган бирми торган махсус суган төрләреннән: батун суганнан һәм төймә суганның әрерәгеннән файдаланалар.* Умартачылык.

КЫЯКЛЫК *и.* Кыяклар (2 мәгъ.) үскән урын; кыяклар үскән җир.

КЫЯМ *и. иск.* Кузгалыш, күтәрелеш (халык арасында). *Көн-төн ишетелеп тора яңа халык кыямы.* Г. Камал.

КЫЯМӘТ *и.* 1. *дини.* Дини тәгълимат буенча: ахыр заман җитеп, Исрафил пәйгамбәр сур өргәннән соң, үлгән кешеләр барысы да терелгәч, аларга алла тарафыннан үткәрелә торган хөкем, суд. — *Яәҗүҗ-мәәҗүҗ кузгалыр, дәҗҗәл чыгар, мәһди күтәрелеп, күктән хәзрәти Гайса иңәр..., җир йөзенең асты өскә әйләнеп буталыр да, кыямәт булыр, дип әйтә икән* [*ишан*], *ди.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. сөйл.* Шау-шулы зур ыгы-зыгы, ары-бире чабыш. [*Сафа:*] *Халык ябалак тавына күченә, кыямәт анда. Түбән оч күперен агызып алып киткән.* К. Тинчурин.

Кыямәт көне *дини.* — *к.* кыямәт 1. [*Зәйтүнә:*] *Барсам да, мин сезгә тик кыямәт көнендә, ходай каршында җавап алыр өчен генә барачакмын.* Ф. Хөсни.

КЫЯМӘТЛЕК: кыямәтлек ата-ана *этн.* — туй үткәрү йоласында: кияү белән кәләшнең атасы һәм анасы ролен үтәүче ир белән хатын, алар өйләнешүчеләрнең гомерлек якын кешеләре булып калалар.

КЫЯР *и.* 1. Кабакчалар семьялыгыннан ашый торган озынча сусыл җимеш (яшелчә) бирә торган үсемлек. [*Хәмидә*], *арт бакчага чыгып, андагы бәрәңге, кыярларны карап чыкты.* М. Гафури. [*Суны*] *кешеләр берөзлексез кәбестә, помидор ояларына, кыяр, чөгендер һәм кишер түтәлләренә юллап тордылар.* Ш. Камал.

2. Шул үсемлекнең ашый торган сусыл яшел җимеше. *Йомышчы малай башын гына селекте дә, кыярын шарт итеп тешләп алганнан соң, чыгып йөгерде.* Г. Бәширов. *Рәүфә, китәргә дип, уракларын хәзерли, кызыл ашъяулыкка икмәк белән кыяр төенли.* А. Шамов.

Кыяр үләне — яфракларыннан кыяр исе килә торган каты төкле берьеллык үсемлек; *русчасы:* бурачник. *Кыяр үләне бик мул бал табышы бирә торган үсемлекләр рәтенә керә.* Умартачылык.

КЫЯРАК *и.* Култык астына яки ботка чыга торган авыртулы шеш, биз. [*Габсәләм:*] *Йөгереп булса ярар иде әле, ботка кыярак чыккан, йөгергәндә авырта.* М. Гали.

КЫЯР-КЫЙМАС *рәв.* Тартынып, оялып, беркадәр курка төшеп. *Бала, читкәрәк китеп, стенага сөялде, ана кыяр-кыймас кына ишек шакыды.* А. Әхмәт.

КЫЯРЛАНУ *ф.* Кыярга төймәләнү, вак кыярлар барлыкка килү (кыяр үсемлеге турында). *Яңгыр кояр кыярларга Кыяр кыярланганда.* Ә. Ерикәй.

КЫЯРЛАУ *ф. диал.* Бакчадан яшелчә яки җимешне күп итеп урлау. *Варис --- малай чакта күршеләрнең алар ягына авышкан шомыртларын кыярлый торган иде.* М. Хәсәнов.

КЫЯРЧАЛАР *и.* Кыяр үләннәре семьялыгы. [*Күкебаш*] *төкләр белән капланган, шунлыктан кыярчалар семьялыгын бераз вакыт кытыршы яфраклылар семьялыгы дип тә йөртканнар.* Робинзон эзл.

КЫЯС: кыяс кылу (итү) *иск.* — чагыштыру, тиңләштерү. [*Бу театр*] *эч пошканнан гына театр уйнарга керешкән* [*һәвәскәрләргә*] *кыяс итәрлек дәрәҗәдән күптән үткән вә үзенә тамашачы күңелен җәлеп иткәндер.* Г. Тукай. *И туган! Минем хәлемне ярканатка кыл кыяс: Калка гаклым башыма, тик үткәч эш, баткач кояш.* Ш. Бабич.

КЫЯФӘТ *и.* 1. Кешенең тышкы күренеше, килбәт. [*Габдулланың*] *кыяфәтендә, төсендә дәү апасы һәм Газизә апасы белән уртак сыйфатлар таптылар.* Ә. Фәйзи. || Кешенең эчке, психик халәтенең, характерының чагылышы буларак тышкы күренеше, төсе. *Солтан, арыган кыяфәт белән баганага сөялеп, маңгаен сыйпады.* Г. Бәширов. *Өйалдында Газинурның аяк тавышлары ишетелгәч, Миңнурый яңадан салкын, буйсынмас кыяфәткә керде.* Г. Әпсәләмов.

2. Нинди дә булса предметның тышкы күренеше, рәвеше. *Бу вакытта дхмәтнең --- юыну бүлмәсе пычранып, авыл мөәзиннәренең мунчалары кыяфәтенә кергән иде.* Ф. Әмирхан. || Күренеш, рәвеш, төс. *Безнең ул самими дуслыгыбызның ахыры мондый авыр һәм күңелсез бер кыяфәт алыр дип, яңлыш кына да уйлый алмаган идем.* Г. Ибраһимов.

3. *әд. иск.* Образ, тип. *Икенче дәрәҗәдәге кыяфәтләрдән Вәли илә Юсыфның кыяфәтләренең яхшылыгына һич сүз юк. Боңлар тәмам-тәмамына бер сыйныф халыкка хезмәт итүчеләрнең кыяфәтләренең җанлы сурәтләредер.* Г. Камал.

КЫЯФӘТСЕЗ *с.* 1. Матур булмаган, ямьсез; шыксыз. *Судья — сузан буйлы, чандыр, кыяфәтсез карт.* А. Әхмәт.

2. *и. мәгъ.* Берәр кешене сүгү, ачулану вакытында әйтелә.

КЫЖРАУ *ф. сөйл.* Бик нык теләү; нинди дә булса эш эшләргә бик нык омтылу. *Соры болытлар --- нәкъ аның сугылып бетмәгән эскертләренә яварга кыжрап йөриләр кебек.* Г. Бәширов. [*Гөлжиһан:*] *Син өйгә кайтып кергәннән бирле нидер әйтергә кыжрыйсың.* А. Расих.

КЫЖЫР-БЫЖЫР *җый. и.* Төрле күңел ачулар. *Егерме яшькә җитеп, кичке уеннар, биюләр, клублар, яшьләргә хас, үзара була торган кыжыр-быжырлар белән артык мавыгып китә алмаган Гәүһәрия --- үзен хиссез кеше дип саный иде.* А. Гыйләжев.

КЫҢГЫР *рәв.* Нинди дә булса яссылыкка карата почмак ясап, беркадәр кырынайтып. *Башыңдагы түбәтәең Килешә кыңгыр кисәң.* Ш. Камал. *Муеннарын сузып, башларын кыңгыр салып, күлдәге үрдәкләр бу тавышны тыңладылар.* А. Алиш. || *с. мәгъ.* Горизонталь яки вертикаль яссылыкка карата почмак ясап торган; беркадәр кырынайган, авыш. *Кыңгыр фуражка астыннан тырпаеп торучы тузгак чәчле бу „киткән башлар“ иртә таңнан ук карта уйнарга тотынганнар ахры.* К. Нәжми.

◊ **Кыңгыр карау** — начар карау, начар мөнәсәбәттә булу. *„Шушма башы“* [*газетасы*] *укучылары, көннән-көн англичаннарга дошманлыкларны арттырып, кыңгыр карый башладылар.* Ш. Мөхәммәдев. **Кыңгыр китмәү** — начар булмау, зарар килмәү.— *Муса энекәш, абзарыңны бу кадәр караганчы, йортыңны карасаң да кыңгыр китмәс иде бит, син буйга җиткән инде, өйләнергә дә вакыт.* Р. Ильяс. **Кыңгыр эш** — начар эш, яман эш. *Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә.* Мәкаль. **Кыңгыр як** — кимчелек, кимчелекле як (кешенең эшендә, характерында һ. б.). [*Нәсимә:*] *Тора башлаганыбызга кырык көн юк, синең инде кырыктан артык кыңгыр ягың килеп чыкты.* Р. Ишморат.

КЫҢГЫРАВЫК *и. сөйл.* Кечкенә кыңгырау; шөлдер. *Нәкъ суреттәгечә киң ыштанлысы, кәмит алдына җыелган халыкка карап, кыңгыравыклы бүреген салды да, җирән чәчен күрсәтеп, бик түбән иелеп алды.* Ә. Фәйзи.

КЫҢГЫРАЙТУ *ф.* Нәрсәне дә булса кыңгыр хәлгә китерү; кыңгыр (авыш) салу (мәсәлән, башны, баш киемен). *Хәзрәт, өйгә кайтышлый, дхмәттән Миңсылу кодачаның үзләрендә икәнлеген ишеткәч, эшләпәсен бераз кыңгырайтып, купшылап куйды.* Ф. Әмирхан. *Җирән айгыр, башын кыңгыраятып, колакларын шомартып, бу нинди әкәмәт мал дигән сыман, үгезгә карап бара.* Ә. Айдар.

КЫҢГЫРАУ *и.* 1. Металлдан (бакырдан яки аның эретмәсеннән һ. б.) киселгән конус рәвешендә ясалган, стенасына бәрелеп яңгыравыклы тавыш чыгару өчен теле булган эче куыш предмет. Нигездә ике төрле була: бер төрлесе шактый зур булып, көчле яңгыравыклы тавыш барлыкка китерә, нинди дә булса сигнал бирү өчен чиркәү манарасына, вокзалга, корабларга һ. б. ш. урыннарга куела. *Чиркәү кыңгыраулары гөрләгән тавыш һаман ишетелеп тора.* Ш. Камал. *Артта, вокзалда, ике тапкыр кыңгырау какты лар.* Г. Гобәй; икенче төрлесе формасы белән кечкенә булып, төрле максатлар өчен (атка, колынга һ. б. ш. хайваннарга тагыла яисә төрле сигналлар бирү өчен) файдаланыла. *Иясе, бу ишәкне урманда табу читен булмасын өчен, муенына кыңгырау такты.* Г. Тукай. *Тиз генә абзарга кердем дә, кырыкмышымны йөгәнләп алып, муенына кызыл комачка бәйләнгән кечкенә кыңгырау тактым.* М. Гали.

2. Кыңгырау тавышына охшаган тавыш сигналлары бирү өчен хезмәт итә торган җайланма, әсбап. *Ул, --- урам як баскычтан күтәрелеп, ике якка ачылмалы, ак буяулы ишекнең уң ягындагы электр кыңгыравының төймәсен басты.* Г. Ибраһимов.

3. Саратов гармоненың бер детале, металлдан эшләнгән эче куыш ярымшар, гармоньның тиешле теленә басканда музыкаль тавыш барлыкка китерә. *Саратский яшел гармонь, Көмеш кыңгыраулары. Бу көмеш кыңгыраулар ның Кичке яңгыраулары дллә нишләтә күңелне.* Ф. Кәрим.

Кыңгырау гөл *диал.* — бик ачык кызыл чәчәкле декоратив үсемлек; *русчасы:* фуксия. **Кыңгырау чәчәк** — шәмәхә яки куе зәңгәр төстәге чәчәге кечкенә кыңгырауга охшаган үлән үсемлек һәм шул үсемлекнең чәчәге; *русчасы:* колокольчик. *Зәңгәр кыңгырау чәчәкләрне өзеп түшеңә кадыйсыңмы, тукранбашлардан такыя үреп башыңа киясеңме --- —синең иркең.* Л. Ихсанова. **Кыңгырау үлән** — канәферсыманнар семьялыгыннан орлык тартмачыгы кыңгырауга охшаган чүп үлән; *русчасы:* хлопушка.

◊ **Кыңгырау кагу** — берәр хәбәр тарату, бөтен кешегә белдерү. [*Арсланов:*] *Нигә инде бөтен совхозга кыңгырау кагарга?* И. Салахов.

КЫҢГЫРАУЛАУ *ф.* Кыңгырау тагу, кыңгырау бәйләү (дугага, атка һ. б.). *Кыңгыраулап җигелгән өч атны кучер атлатып кына китерә.* Г. Ибраһимов.

КЫҢГЫРАЮ *ф. сөйл.* Кыңгыр хәлгә килү; беркадәр бер якка кырынаю, авышу. [*Салих:*] *Син, кеше башың белән, түмгәк өстендә кыңгыраеп торган чәлән төсле,ялгызың дөнья көт!* Г. Мөхәммәтшин.

КЫҢЫМ *аваз. изәр.* Тамак кырган вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Галиәкбәр агай --- контор баскычына күләнкәгә утырып, „кыһым“ диеп бер тамак кырды.* Ш. Мөхәммәдев.

КЮВЕТ *и.* Юлның ике ягында су агып төшә торган канау. [*Машиналар*], *газларын киметеп, кюветка шуып төшәрдәй булып читкә тайпылалар.* М. Хәсәнов.

КЮВЕ'ТА *и. махс.* Фотографик пластинкаларны, фоторәсемнәрне эшкәртү һәм юу өчен кечкенә савыт. *Пластинкаларны һәм яссы пленкаларны кюветаларда, роликлы киноленканы кюветада яки бачокта эшкәртәләр.* Фото сөюче...

КЮВЕ'ТКА *и. махс. к.* кювета.

КЮРАСО *и.* Апельсин ликеры.

КЮРЕ *и. дини.* Католикларда: мәхәллә рухание, дин башлыгы.

КЮРИ[1] *и. махс.* Радиоактивлыкны үлчәү берәмлеге.

КЮРИЙ *и. махс.* Менделеев таблицасында тәртип номеры 96 булган химик элемент (ясалма юл белән табылган).

КЯЗИП *и. иск.* Ялганчы, алдакчы. *Бу дөньяда - - - Садыйк исемле кязиплар - - - күп бит.* Г. Тукай.

КЯМИЛ *с. иск. к.* камил. *Нидәндер койрыксыз булу я бер уңмаганлыктан, я гакыл кямил түгеллектән санала иде.* Г. Тукай.

КЯМИЛӘН *рәв. иск.* Бөтенләй. *Октябрь[ның] унnarынnан соң матди җәһәт бик начарланган вә әти берлә арамыз кямилән суыгаеп җиткән иде.* Ф. Әмирхан.

КЯР *и. иск. к.* дару 1.

Кяр итү (кылу) — 1) дәвалау, шифасы тию. *Күгәрченкәем шунда ук ава, Кяр итми дәва.* Г. Тукай; 2) тәэсир итү, йогынты ясау. *Үшән атка камчы кяр итмәс.* Мәкаль.

КЯРХАНӘ *и. иск.* Мастерской, берәр нәрсә эшләп чыгара торган оешма; бина. *Кярханәдә эшләү.*

КЯСА, КЯСӘ *и. иск. к.* кәсә 1. *Хур сыйфатлы матурлыгың кясасыннан Мәхәббәт шәрабыны мин дә эчтем.* М. Гафури. *Кытай кясәләрендә ак, кызыл, төрле шәраплар бар.* Г. Тукай.

КЯТИП *и. иск. к.* катип. *Шул ук Бәхет килгән заманда икенче кардәше мәхкәмәдә кятип иде.* Г. Тукай.

КЯФ *и. иск.* Татар телендә гарәп графикасы гамәлдә булган вакытта нечкә „к“ (кь) хәрефенең исеме. [*Сүз*], *саңгырау кяфлар гарәпчәдә булмаганга күрә, үзгәртелмәде.* Г. Тукай.

КЯФЕР *и. иск.* Ислам динендә: динсез, дингә ышанмаган кеше. *Сәйдәш бабай һәм компаниясе театр уйнаучыларны кяфер ясарга статья эзлиләр.* Ш. Мөхәммәдев. || Мөселманнарда башка дин кешесенә кимсетеп бирелгән исем. *Йөрәкне хәзер генә җылытып торган сөекле Михаил сурәте әллә кая китте дә аның урынына „кяфер“ Михаил сурәте килеп басты.* Ф. Әмирхан.

КЯФЕРЛЕК *и. иск.* Ислам динендә: башка диндә булу, башка динне тоту. *Европа „кяферләренең“ мөселманнарны гына түгел, - - - бөтен шәрык халкын кол итеп талауларын, - - - шуңа күрә монда эш кяферлектә түгел, башка нәрсәдә икәнен искә алмадылар.* М. Гафури.

КӘБАБ, КӘБАП *и. иск.* Турыдан-туры утта кыздырылган ит, куырма; шашлык. *Уңган хатын арыш онын кәбаб итәр.* Мәкаль. *Дию өчен көн дә йөз учакта Кәбап кыза адәм итеннән.* М. Җәлил.

◇ **Кәбап итү (күңелне, йөрәкне һ. б.)** — бик нык кайгыга төшерү, бик нык көйдерү, әрнетү, яндыру. [*Зөһрә:*] *Хәнҗәреңнән кискен сүзләр белән Итмәсәң-че кәбап күңелне.* Ф. Бурнаш.

КӘБЕН *и. иск. этн.* Никах йоласы, никах. [*Хәмидә:*] *Вәгъдә бирнәсенә дә, кәбен бирнәсенә дә, актык бирнәгә дә чачагы-чугы белән бик әйбәт, калын ука тирәкле асыл бирмәкче булалар.* Г. Камал.

КӘБЕСТӘ *и.* 1. Әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан бакчада үстерелә торган яшелчә. *Калмас [кәҗәдән] кәбестә, суган кыяклары. — Һәр суганның башын кыркып йөрер.* Г. Тукай. *Яланаяклы бер кызчык кәбестәләргә су сибеп йөри.* И. Гази.

2. Шул яшелчәнең күчән булып, уралып үскән һәм ашамлык итеп кулланыла торган яфраклары. [*Нуретдин:*] *Дә Сөембикә сеңелкәш үзенең яшелчә бакчасыннан алган кәбестәсеннән, кишереннән, помидорыннан һәр көз диярлек безгә өлеш чыгарып килә.* Ә. Еники. *Әхмәт көз көне аннан ярты капчык кишер, алты баш кәбестә алып кайткан иде.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Кәбестәдән хәзерләнгән, кәбестә салып пешерелгән. *Кәбестә бөккәне. Кәбестә бәлеше.* ▭ *Анда боларга, аерым калай савытларга салып, дуңгыз итеннән пешергән кәбестә щие белән эченә яшел киндер мае салган борчак боткасы бирделәр.* М. Гали.

3. Кәбестә корткычларын белдергән тезмә исемнәрнең состав кисәге. *Кәбестә бете. Кәбестә көясе. Кәбестә чебене.* ▭ *Кәбестә күбәләкләре, кәбестә ябалакчыклары һәм көяләр яфракның аскы ягына вак кына йомырка салалар.* Йорт эшләре.

Кәбестә суы *сөйл.* — кәбестә салып пешерелгән аш (гадәттә итсез була). — *Аларның ашаган азыклары: икмәк, бәрәңге, тозлы кыяр илә кәбестә суы, борчак ашы кеби нәрсәләрдер.* З. Бәширн.

КӘБИР *с. иск.* Зур, олы, бөек.

КӘБИСӘ: кәбисә ел — өч ел үткән саен дүртенче елны була торган, 366 көнле ел (29 нчы февраль өстәмә көн булып керә). *Цифрлары 4 кә калдыксыз бүленә торган елларны кәбисә ел дип исәпләргә сүз куешканнар.* Астрономия.

КӘБӘМ *и. диал. к.* бәбкәм, жаным. — *Йә, тагы уйна әле, кәбәм.* Г. Гобәй. [*Килен:*] *Дәшермен, кәбәм, дәшмәгән кая, Солтан абзыкай белән парлап дәшермен!* Г. Бәширов.

КӘВЕС *и. диал. к.* кавыз. *Сугыш вакытында [тегермәннең] куласаларын ваткалап, ягып бетергәннәр, кәвес такталарына хәтле ботарланган иде.* Х. Сарьян.

КӘВЕШ *и.* Йомшак күннән тегелгән кунычсыз аяк киеме. *Казанга баручы аркылы икә улына да пардан - - - сауры үкчәле шыгырдавыклы кәвеш алдырды.* М. Гали. *Бу юлы ул, кисәтми-нитми, Гөлкәй белән икесенә бер очтан камзул белән чалбар, читек белән кәвеш, күлмәк белән кәләпүш тектереп кидерде.* Ә. Фәйзи.

КӘВЕШЧЕ *и.* Күннән кәвеш тегүче. *Бичара бу адәм дә чикте җәфаны: астында кабак, төн буе җырлыйлар, сугышалар, күрше бүлмәләрдә кайсы кәвеш-че, кайсы тегүче.* К. Насыйри.

КӘВЕШЧЕЛЕК *и.* Һөнәрчелекнең бер тармагы буларак, кәвеш тегү эше. *Кәвешчелек белән шөгыльләнү.*

КӘВЕШЧӘН *рәв.* Кәвеш киеп, кәвеш кигән килеш.

КӘГАЗЬ *и.* 1. Чүпрәк-чапрактан, агачтан яки башка әйберләрдән ясалып, язу, китап басу, әйберләр төрү һ. б. максатлар өчен кулланыла торган юка табаклардан гыйбарәт материал. [*Фатиха*] *өстәлгә җәйгән кәгазьне алмаштыра, кара чәчрәп беткән иске кәгазьне Нәсимәгә күрсәтә.* А. Әхмәт. *Хатлар яздым утырып, Ак кәгазьләр тутырып.* Җыр. || *с. мәгъ.* Кәгазьдән ясалган, кәгазьдән әзерләнгән. *Кәгазь пакет. Кәгазь капчык.* ▭ *Низами карт, - - - сәке түренә, тәрәзә яктысына аяк бөкләп утырып, иске киемнәрне турап, сәкегә кәгазь өлге салып, тәвәккәл бүрек тышлыгы кисә.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Кәгазь ясап чыгара торган, кәгазь әзерли торган; кәгазь саклый торган. *Кәгазь фабрикасы. Кәгазь комбинаты. Кәгазь склады.*

2. *сөйл.* Рәсми характердагы язма документ. — *Хәзер - - - контракт кәгазен барып алып кайтасы гына калды.* И. Гази. [*Агай:*] *Кыз алу, кыз бирү кечкенә эш түгел, ике арада кәгазь языйк.* Әкият. || Нинди дә булса таныклык, мандат, шәхес таныклыгы. [*Госманов:*] *Шуның өстенә зур улы Сөләйман аңа Кожтрест агенты дип кәгазь бирдергән, ә ул шул кәгазь белән гөрләтеп тире белән сәүдә итеп ята.* Һ. Такташ. || Жалоба, жалоба язуы. [*Шәрип*] *тагы ике фәкыйрьгә унар пот арыш, берәр сум акча бирде дә Гыйззәтнең бер хатасы турында эш кузгаттырды: „Яше тулмаган кызга никах укыды“, — дип, кәгазь бирдерде.* Г. Ибраһимов.

3. Язылган яки тексты булган теләсә нинди бит, табак кисәге. *Уң якта зур өстәл, анда графин, стакан, озын саплы кыңгырау, әш кәгазьләре, өстәл артында судья, аның янында секретарь утыра.* А. Әхмәт. [*Офицер*] *кулындагы бер кәгазьне фонарь яктысында әйләндерә-әйләндерә укырга кереште.* К. Нәҗми.

4. *күч.* Кәгазь акча. *Әнвәр бишлек кәгазь чыгарып Мөгълифәнең кулына суза.* Г. Камал. *Шул арада ук ниндидер солдат, итекченең кулына 5 тәңкәлек кәгазь төртеп, итек алып маташа.* Г. Тукай.

Кәгазь акча — дәүләт тарафыннан чыгарылып, әйләнештә алтынны алыштыра торган, дәүләт эчендә кабул итү мәҗбүри булган һәм алтынга алыштырылмый торган, кәгазьгә төшерелгән акча билгесе. *Биктәһир карт, портмонетны ачып, аның урта бүлекчәсеннән бер сумлык кәгазь акча тартып чыгарды.* И. Гази. **Кәгазь ясау** *гади с.* — рәсми һәм билгеләнгән тәртиптә килешү, килешү ясау. [*Мужик:*] *Менә без, бай абзый, тагын сүзгә керешеп китәрбез, син тагын юк сүз сөйлисең дип әйтерсең, менә без үзебезнең арабызда кәгазь ясыйк.* Әкият.

◇ **Кәгазь миллиардер** *кимс.* — бәясе бик нык төшкән кәгазь акчаларга гына ия булган миллиардер. [*Фазыйл:*] *Мин Чех-Колчак белән бергә Себердә кызылларга каршы сугышып йөргән чакта* [*Гәүһәр*] *ниндидер вак приказчиктан кәгазь миллиардерга әйләнгән бер спекулянтка кияүгә чыккан.* Г. Ибраһимов.

КӘГАЗЬЛӘНҮ *ф. сир.* Кәгазь белән әйләндереп алыну; кәгазь белән каплану, кәгазь ябыштырылу. *Дивар аксыл җирлектә зур-зур бизәкле кәгазь белән кәгазьләнгән.* Ф. Әмирхан.

КӘГЪБӘ *и.* 1. *дини.* Согуд Гарәбстанының Мәккә шәһәрендәге сөнни мөселманнар күктән иңгән, изге дип санаган кара таш куелган һәм хаҗга баруның төп максаты булган мәчет. *Кәгъбәгә бару.* □ *Дөя кәгъбәгә бару белән хаҗи булмас.* Мәкаль.

2. *күч.* Күңелне, игътибарны бик нык җәлеп иткән әйбер яки күренеш. *Ул кадерле рәсем дә Михаил өстәленең иң кадерле урынына барып басты да китап карап арган күзләрнең ял итә торган бердәнбер кәгъбәсе булып торды.* Ф. Әмирхан.

3. *күч. тарт. форм.* **кәгъбәм** — кем дә булса яраткан, сөйгән кеше; кемнең дә булса бөтен күңелен биләп алган кеше. [*Зөһрә:*] *Кара чәчләреңнән сөясөя, кемгә „сөям, кәгъбәм!“ диярмен!* Ф. Бурнаш.

КӘГЪБӘТУЛЛА *и. дини. к.* кәгъбә 1. [*Хаҗи:*] *Мин Кәгъбәтуллада хаҗ кылган вакытта бер хикмәтле төш күрдем.* Ш. Камал.

КӘГҮ *ф. гади с.* Аракы эчү, исерткеч эчемлек эчү. *Дустым Харис шунда яшәп ята, Ярата шул бераз кәгәргә.* Х. Камалов.

КӘЕФ *и.* 1. Кешедә теге я бу физик хәлгә яки кичерешләргә бәйле рәвештә барлыкка килгән хис, рухи халәт. [*Мохтар:*] *Күршенең кәефе зарарсыз, кичәгенәк азрак сөйләшеп утырган идек.* Ш. Камал. || *сөйл.* Кешенең үз-үзен нормаль сизүе, сәламәт булуы турында. — *Кичәдән бирле каефең юк, әллә авырыйсыңмы?* Р. Ишморат. || *сөйл.* Күңел. *Бу соңгысы халыкның кәфенә бигрәк ошап калды.* Г. Ибраһимов.

2. Кәеф-сафа, күңел ачу. — *Минем үз иркем, теләсә кая барам, мин, синең төсле, бөтен гомеремне берәүнең кәефе өчен фида итмим.* Г. Тукай. *Бик аз гына кешеләрнең кәефе өчен Бичара ач халыкны һич тә сатмам.* М. Гафури.

3. *күч. сөйл.* Исерткеч эчемлекнең күңелне ача торган көче. *Сүзләр кабынды. Кымызның кәефе мигә йөгерде.* Г. Ибраһимов.

4. *хәб. функ. күч. сөйл.* Кыйммәт, югары бәяле. — *Чайка-2 телевизорын сатып алдым. Бәясе дә кәеф кенә: бөтен кирәк-яраклары белән 407 сумга төште.* Соц. Тат.

◇ **Кәеф ачу (кору)** — күңел ачу, кәеф-сафа итү. *Ашау-эчү, кәеф кору, кәеф кору — Байбикәнең уйлары, уйлары.* Г. Камал. **Кәеф ачылу** — күңел ачылу, кәеф күтәрелү, яхшы кәеф барлыкка килү. [*Шөҗаг:*] *Минем дә бераз кәеф ачылып китте, тукта әле, тагын берәрне алдырыйк.* Г. Камал. **Кәеф килү** — кәеф күтәрелү, яхшы кәеф барлыкка килү. *Сәйфулла бу сүздән кәефе килеп елмайса да, дәшә алмый калмый.* Ә. Еники. **Кәеф китерү** — яхшы кәеф барлыкка китерү, кәефне күтәрү. *Толчокчыларның — кәефләрен китергән Карәхмәт Тукай поэмасында иң көлке бер сурәт итеп алына.* М. Җәлил. **Кәеф китү (бозылу, кырылу)** — 1) яхшы кәеф юкка чыгу, бетү. *Үзенең кыш буе узганнары белән абыйсының исен китәргә уйлап торганда, аның үзен болай кимсетүенә Габделкаюмның шактый кәефе китте.* М. Гали. *Әллә ашыйсы бик килгәнгә, әллә башкага, шул арада аның кәефе бозылып та өлгерде.* Г. Бәширов; 2) хәтер калу, үпкәләү. *Каюм, Әхмәтнең Фәрихәгә кәефе киткәнен сизеп, мәсьәләне тизрәк ачарга тиеш тапты.* Ш. Камал. **Кәеф килеп чыгу** *сөйл.* — әйбәт килеп чыгу, яхшы булу. *Көйгән пәрәмәчләрнең итен, ите чи калганнарының камырын ашадылар, һәм гажәп кәеф килеп чыкты.* Ш. Хөсәенов. **Кәеф кылу** *иск.* — *к.* күңел ачу. *Бер кичне Батыргали агай зур гына бер трактирда кәеф кылып утырганда, коньяклар, ромнар чамадан артыграк әсәр кылып, күз аллары томаланна башлады.* Ш. Мөхәммәдев. **Кәеф сөрү (чигү)** — күңел ачу, кәеф-сафада яшәү. *Күрдем әле синең залимеңне: һаман кәеф сөрә, типтерә.* Г. Тукай. **Кәеф хушлану** — *к.* кәеф килү. *Бу хатны укыгач, Галиәкбәр агайның бераз кәефе хушланган иде.* Ш. Мөхәммәдев. **Кәефне бозу (кыру, җибәрү)** — яхшы кәефне юкка чыгару, күтәренке кәефне бетерү. *Кавказның көзге яңгырлы һавалары, җылы вә йомшак томаннары кәефне бозмый, — дәртләндерә, уйландыра, хыялландыра.* Ш. Камал. *Егетнең бу зары Хәйдарнең бөтенләй кәефен кырды.* Г. Бәширов. *Ләкин машинистның бу турыда әйтеп Хәлимнең кәефен җибәрәсе килмәде.* Г. Гобәй. **Кәефне табу** — кемдә дә булса яхшы кәеф барлыкка китерү, кемнең дә булса кәефен күтәрү. *Бу юлы инде ул Зифа карчыкның кәефен табарга, аңа ошарга тырыша.* А. Шамов.

КӘЕФЛЕ *с.* 1. Күңелле; күңелгә ошый торган. *Габделбасыйр күзләре йомык халәттә шактый вакытлар бу матур һәм кәефле күренешне сәйяр итеп ятты.* Ф. Әмирхан. || Кәефе яхшы, кәефе күтәренке, күтәренке күңелле. *Ул кәефле чакларында иптәшләренә үзенең электә бер бай баласы булып та, соңыннан фәкыйрьләнгәнлекләрен — сөйлидер иде.* Ш. Камал. | *рәв. мәгъ. Хәйрүш — кәефле елмая.* М. Җәлил.

2. *күч.* Бераз исергән, кызмача. *Башкаларның чикәләре кызарды, йөзләренә тир чыкты, исереклек, кан тамырлары буена тарала биреп, кәефле, бераз кызмача хәлгә керде.* Г. Ибраһимов.

КӘЕФЛЕЛЕК *и.* Кәефле булу, яхшы кәеф булу; яхшы кәеф. *Сәмигулла абзый бүген кич буена — хосусый бер кәефлелек хис итеп торды.* Ф. Әмирхан.

КӘЕФЛӘНДЕРҮ *ф.* Кәефен күтәрү, күңелен күтәрү. — *Син мине чакырып, кәефләндерәм дигән булып, тик күңелемне генә болгатасың.* Г. Тукай.

КӘЕФЛӘНҮ *ф.* 1. Яхшы кәеф барлыкка килү, кәеф күтәрелү. *Зиннәт — ничектер тагын да кәефләнә төшеп, алар күрсәткән сукмак белән Идел ярыннан китте.* Г. Бәширов. *Халык, Сибгать абзый-*

ның чамадан тыш юмартланып китүенә кәефләнеп, көлеп җибәрде. А. Шамов. || Рәхәтләнү, рәхәтлек сизү; хушлану. *Кәефләнеп чәй эчү.*

2. Исерткеч эчемлек эчеп кызмача хәлгә килү, кәеф күтәрелү. *Кунаклар мамык мендәр өстендә генә утыралар, ашыйлар, кымыз эчәләр, кәефләнәләр.* Г. Тукай. *Майлы күзле майор бу сыйдан кәефләнде, тәмам исерде.* М. Җәлил.

КӘЕФЛӘП *рәв. сөйл.* Кәефле итеп, күңелле итеп. *Дачада егетләрнең күплеген, хәзер инде аларның һәммәсе белән үзенең танышып җиткәнлеген Лиза үзенә бертөрле кәефләп сөйләде.* Ф. Әмирхан.

КӘЕФ-САФА *и.* Эчү, типтерүдән гыйбарәт кайгысыз, күңелле тормыш; күңел ачу. *Революция бастырылганнан соң --- [бай малае Йосыфҗан] тәмам кәеф-сафага бирелде.* Г. Нигъмәти. || Рәхәтлек бирә торган кызык һәм уен-көлке; хозур эш. [*Байлар*] *эчәләр, кәеф-сафа табалар, жуликлык һәм аферистлык юллары белән төрле махинацияләр коралар, халыкны алдыйлар.* Х. Хәйри.

◇ **Кәеф-сафа сөрү (кылу, кору)** — нинди дә булса кызык һәм уен-көлке белән күңел ачу. *Бик аз гына санлы буржуазиянең кәеф-сафа сөрүләрен, аларның мәнфәгатьләрен саклап калыр өчен, эшчән халыкның фронтларда газап чигүләрен күрәбез.* М. Гафури.

КӘЕФСЕЗ *с.* Кәефе начар булган; күңелсез. *Кәефсез вакыт.* □ *Хәзрәт тә, озак тормый, кәефсез бер хәлдә чыгып китте.* М. Гафури. || *рәв. мәгъ.* Күңелсез, күңелсез рәвештә. *Һәм кәефсез генә кайтып кердең өйгә, бер сүз дәшмәдең.* М. Җәлил. *Өй эчендә һәммә кешене күңелсез вә кәефсез күрдем.* Г. Тукай.

КӘЕФСЕЗЛЕК *и.* Кәеф булмау, кәеф юклык; күңелсезлек. *Аларның эченнән Хәсәнгә генә тоела торган бер кәефсезлек, бер эч пошыру аңкып тора иде.* Ф. Әмирхан. *Д бүген, сый-хөрмәттән кайтуына карамастан, аның [Нәгыймнең] кәефсезлеге кечкенә түгел иде.* Ш. Камал.

КӘЕФСЕЗЛӘНДЕРҮ *ф.* Кәефне җибәрү, күңелне төшерү. *Җәмиләне шул икмәк мәсьәләсе саргайткан, --- шул икмәк юклык аны кәефсезләндергән.* М. Гафури.

КӘЕФСЕЗЛӘНҮ *ф.* 1. Кәеф китү, кәеф бозылу, күңел төшү. *Тик Ибрай аңа карап кәефсезләнмәде, кирәсенчә, үзе теләп шулай әйттергән төсле, әлектереп алып китте.* М. Әмир.

2. *күч. сөйл.* Чирләү, авыру. *Галимә апаның авыруы, кәефсезләнүе бетмәде.* М. Гафури.

КӘЕФ-ХӘТЕР *и. сөйл. к.* кәеф 1. [*Хөснетдин:*] *кәеф-хәтерләрегез ничек, хажи әфәнде?* Ш. Камал.

КӘЗ I *и. к.* кәс. [*Шәрифҗан:*] *Менә бу төшен шулай уеп аласыз да пулемет куяр өчен түгәрәк урын ясыйсыз. Аннары чирәмле кәзләрдән бруствер өярбез.* И. Гази. *Юл буендагы канауларга кәз түшәлеп, чөйләнгәннәр.* М. Хәсәнов.

КӘЗ II *и. иск.* Аршын. [*Бай хатыныныңның*] *калфак төбе ике кәз.* Н. Исәнбәт.

КӘЗБЕРӘ *и. сөйл.* Дару үләне.

КӘЗЛӘҮ *ф. к.* кәслә. *Көньяк һәм көнбатыш тау битләрендә күпьеллык үләннәрдән буфер полосалары ясалырга, кәзләү, агач утырту чаралары үткәрелергә тиеш.* А. Фаткуллин.

КӘЗ-КӘЗ: кәз-кәз басып бару (атлау) — гәүдәне туры тотып, аякны каты гына басып, вак-вак адымнар белән көязләнеп бару (атлау). *Уникешәр бала итәкле зәңгәр, яшел, алсу күлмәк кигән кызлар, кәз-кәз басып, чулпыларын чылтыр-чылтыр китереп, каядыр йомыш белән баралар.* Г. Бәширов.

КӘЗӘКИ *и. сөйл. к.* казаки. *Бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштанларым, читекләрем, кәзәкиләрем тузгач, әти үзенең мин киләмәстән бер ел элек үлгән угылының күк киндер күлмәге илә бишмәтен миңа бирмәкче булды.* Г. Тукай.

КӘЗӘНКӘ *и. диал.* Чоланда азык-төлек саклау өчен ясалган караңгы бүлмә. [*Хәлим*] *әнкәсенең яшереп куйган шикәрен чәлергә кергән чакта --- кәзәнкә ишеге шыгырдый башлый торган иде.* И. Гази.

КӘЙ *с. диал.* Начар, алама; яман. [*Фатыйма:*] *Кәй кеше булып чыктың син болай булгач.* А. Расих. || Начар, зәгыйфь. *Аннары, янчык саен йөзәр генә бодай алып, тишелдереп карыйсы. Менә шул әйтеп бирә инде ул: йөздән ничәсе тишелә? Уҗымы көр буласымы, уртачамы, әллә кәй үкме?* Г. Бәширов.

КӘЙЛӘ *и.* Тау токымнарын һ. б. ш. вату яки ватып алу өчен хезмәт итә торган, агач сапка утыртылган, бер ягы очлы, озын чүкеч сыман тимер корал. *Эшчеләр һәммәсе көрәкләр, кәйләләр белән ашыгып-ашыгып казыйлар.* Ш. Камал. [*Булат:*] *Тезләнеп ятып тирән базларда, Кәйлә уйнатып эшлиләр анда.* К. Тинчурин.

КӘЙЛӘНҮ *ф. диал.* Начарлану, кирегә китү. — *Минем эш бераз кәйләнә башлады, ләкин читкә үк барып терәлмәгән иде әле.* Г. Ризван.

КӘЙТӘН *и.* Күлмәккә һ. б. ш. тоту өчен кулланыла торган бизәкле үрелгән җеп яки тасма.

Кәйтән ялау *иск.* — шундый җептән ясалган кием әлмәге. *Безнең авылга кәйтән ялау урынына бишмәткә тишеп төймә урыны ясый торган --- төгүчеләр килә башлады.* М. Гали. *Корбангали --- [Садыйкның] җилән ялавын, шул вакыттагы соңгы мода буенча, тишеклән ясаган иде. Д Садыйк[ка] --- кәйтән ялау дип атала торган борынгы ялау кирәк булып чыкты.* Ф. Хөсни.

КӘЙФИЯ *и. күч. иск.* Күңел ача торган урын (кабак, мәйханә һ. б.ш. урыннар турында). *Ач авыл, мохтаҗ авыл! Җимерек өй каршында ич Ожмах кеби кәйфиясе.* Г. Тукай.

КӘКЕРЧЕК *и.* Сабанга мичәү аты җигү өчен күчәргә беркетелгән нечкәрәк кәкре агач. *Кәкре агачтан — кәкерчек, туры агачтан — чата.* Мәкаль.

КӘКЕР-ЧӨКЕР *җыйд. и. диал.* Чәй яны азыклары, чәй ашлары. [*Суфия*] *ашны бер-ике кашык кына капты, чәй янындагы кәкер-чөкерләрдән бары ярты печенье генә сындырып ашады.* А. Расих.

КӘККУК I *и. сөйл. к.* күке. *Нәкъ шул минутта сылу кәккүк янә бер-ике тапкыр талпынып кычкырды да яшь каен өстеннән күтәрелде.* Ә. Еники. *Кайсыдыр агачның башында, су эченнән ишетелгәндәй, йомшак ягымлы тавыш белән кәккүк моңая, урман күгәрченнәре гөрли.* Г. Бәширов.

Кәккүк чәчәге — канәферсыманнар семьялыгыннан күпьеллык үсемлек; *русчасы:* кукушкин цвет. *Кәрешкә, мәтрүшкә, кәккүк чәчәкләре --- белән чуарланган, әле чабылып өлгермәгән болынның хуш исле җиләс һавасына туйганчы иркәләндек.* М. Әмир.

КӘККУК II *аваз ияр. к.* кәк-күк. *Калын урманда, Гел кичкә каршы, Ишетелә моңлы Бер кошның тавышы: Кәккүк, кәккүк, кәккүк, кәккүк!* М. Җәлил.

КӘК-КҮК *аваз. ияр.* Күке кычкырган тавышны белдерә. *Кәк-күк, кәк-күк, кәккүк кычкыра микән?* Ә. Фәйзи.

КӘКРЕ *с.* 1. Туры, төз булмаган, бөгелгән яки кәкрәйтелгән. *Кәкре таяк.* □ [*Кендекнең*] *нечкә очына кечек тишек аркылы кәкре кадак үткәрелгән.* Г. Ибраһимов. || Туры булып үсмәгән, турыга үсмәгән. *Кәкре мөгез.* □ *Яр буендагы кәкре өянкеләр, ялангач ботакларын салындырып, суга карап, хәйран булып тынып калганнар.* А. Шамов.

2. *сөйл.* Бөкре, бөкресе чыккан; кәкрәйгән. *Д кәкре карчык тагын ырылдый башлауга, Илдар, үзен тотып тора алмыйча, аның каршысына йөгереп килде.* Г. Гобәй.

3. *мат.* Туры булмаган, бөгелгән (сызык турында). *Синусоиданы төзү өчен ул ноктaларны лекало ярдәмендә шома кәкре сызык белән тоташтырырга кирәк.* Тригонометрия. || *и. мәгъ.* Туры булмаган сызык. *Х абсциссасы чиксез зурайтылганда, кәкренең ординаталары кимегәннән-кими барып, нульгә якынлашалар.* Алгебра.

4. *күч.* Гадел булмаган, турылыксыз; дөрес булмаган, ялгыш. *Иске заманның бер падишаһы, үзенең кәкре фикере илә, гыйлемнең файдасыннан күбрәк зарары барлыгын тапты.* Г. Тукай. [*Доронин*] *кәкре эшләре турында сигнал биргән намуслы укытучылар[ны] эштән чыгару турында приказ бирде.* Соц. Тат. || *и. мәгъ.* Гадел булмаган эш; кыңгыр эш, ялган. *Укымак — дөреснең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң уткен, иң кирәкле коралдыр.* Г. Тукай.

Кәкре аяклы — аяклары туры булмаган, чалыш аяклы; камыт аяклы. *Тәрәзә яныннан кәкре аяклы бер кибетче узып китте.* Ф. Әмирхан. *Дә кәкре аяклы япь-яшь бала Тәпи йөреп чыга урамга.* Һ. Такташ. **Кәкре борынлы** — сырты калкып, кәкрәебрәк торган борын. *Кәкре зур борынлы, уткен күзле, зур тупас гәүдәле бу кеше: „Алай булгач, сиңа монда тору авыр булыр", — диде.* М. Гафури. **Кәкре муен(лы)** — муены туры булмаган. *Крестьяннар --- барыбер элекке чә аны „кәкре муен Сәләхи" дип кенә йөртәләр иде.* Ш. Камал.

◇ **Кәкре кабыргалы** — тиз үпкәләүчән. **Кәкре каенга терәтү (терәү)** — алдау, алдап берәр нәрсәсез калдыру. — *Син Хафизны кәкре каенга терәткән кебек, ул да мине кәкре каенга терәтеп куймаса ярар иде.* Р. Ишморат. *Дингә ышанучы Хәерниса апа белән Гыймай абзыйның нечкә кылларын белеп алган хәйләкәр Лидия аларны кәкре каенга терәп китә.* Соц. Тат. **Кәкре килү** — *к.* кәкрегә бөкре килү. *Үч иткән шикелле бит, аңарга гына кәкре килеп тора.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Кәкре китерү** — кирәксез эш эшләү; берәр комачау барлыкка китерү. *Хуҗалыкны яңабаштан корып йөргән --- вакытта [улының] укырга китүен карт акылсызлык дип саный иде. „Бик кәкре китердең, улым, бик кәкре китердең", — диде ул.* Г. Ахунов. **Кәкре койрык** — эт. *Башны күргәч, --- Өрде барча итчеләрнең этләре. Йөгерәләр аллы-артлы бер көтү Кәкре койрыклар! Кая башны җитү.* Г. Тукай. **Кәкре кул(лы)** — урлый торган, урлашучан (кеше). [*Мәликә:*] *Кырдан эшләрне җыеп бетергәч, аер да җибәр. --- Андый кәкре куллы, хәерче кызын асрар хәлем юк.* А. Шамов. [*Шәфыйк*] *аз гына кәкре кулларга ияреп китмәгән.* Б. Камалов. **Кәкрегә бөкре килү** — нинди дә булса бер эш барып чыкмау; берәр эшне башкару юлында комачау барлыкка килү. [*Насыйбулла:*] *Безнең ише ярлыларга җир бүленер дигәннәр иде, кәкрегә бөкре килде куйды.* И. Туктар. **Кәкрене кыекка саплау** — ялгыш аңлау яки сөйләү; аңлы рәвештә ялган сөйләү. [*Маһи:*] *Авыздан тартып алырга җыенганым юк иҗ әле, ахирәт, бигрәк тагын син кәкрене кыекка сапларга торасың.* Ф. Хөсни.

КӘКРЕ-БӨКРЕ *с.* Төрле юнәлештә кәкрәйгән, кәкрәеп беткән. *Кай минутларда [агачлар] кәкре-бөкре ботаклары белән киемнәребезне эләктереп җибәрми торалар.* А. Шамов. *Кәкре-бөкре хәрефләр тезелгән юллар буенча абыстайның бармаклары шактый тиз йөриләр.* М. Гали. || Туры булмаган; бер бу якка, бер теге якка борылган. *Кәкре-бөкре ямьсез урамнары, өйләрендә тычкан утлары.* М. Гафури. *Кәкре-бөкре тыкрыкларны үттек.* Х. Кәрим.

КӘКРЕЛЕК *и.* 1. Кәкре булу, кәкрәйгән булу. *Агачның кәкрелеге.*

2. *мат.* Туры сызыктан читкә авышу дәрәҗәсен билгели торган зурлык. *Сызыкның кәкрелеге. Кәкрелек үзәге.*

3. *күч.* Гадел булмау, гадел түгеллек. *Менә без хәзер шул кешеләр ясаган тәртипләрнең турылыгы, кәкрелеге хакында сүз сөйләшмәкче булабыз.* Г. Тукай.

КӘКРЕЛӘНҮ *ф. сөйл. к.* кәкрәю. *Брюкасы да күптәннән үтүкләнмәгән ахрысы — тез башлары ике якка кәкреләнеп кыйшаеп торалар.* Ш. Камал.

КӘКРЕСЫЗЫКЛЫ *с. махс.* Туры булмаган сызыклы, туры булмаган сызыктан гыйбарәт. *Дөбернең хәрәкәте турысызыклы һәм кәкресызыклы хәрәкәтләргә бүленә.* Физика.

КӘКРӘ: кәкрә үлән — иген арасында үсә торган себеркәч чәчәкле чүп үлән; *русчасы:* метлица.

КӘКРӘЙТҮ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса кәкре хәлгә китерү, бөгү. *Ана дуңгыз бик аптыраган, шул койрыкны тагып алган да кәкрәйтеп салган.* А. Алиш. [*Ул*], *имән бармагын кәкрәйтеп, берсенең маен каерып алды да, аны иреннәрен чәпелдәтә-чәпелдәтә тәмләп, шунда ук икенчесенә сузылды.* Г. Бәширов.

2. *сөйл.* Авызга табигый булмаган рәвеш бирү, кыегайту. — *Салмасәпкәй улы да, авызын кәкрәйтеп: „Алар синең улың кебек авызларында чебеннәр уйнатмыйлар", — дигән була.* Һ. Такташ.

КӘКРӘЮ *ф.* 1. Кәкре хәлгә килү, бөгелү. [*Шакир*] *башлары кәкрәйгән, астына салынган, кыска балтырлы киез итек күтәреп чыкты.* А. Алиш. *Юл буендагы кәкрәеп үскән, ябалдашлы юкә агачы төбенә барыбыз да ял итәргә утырдык.* М. Гали. || Турылыгын югалту, бөкрәю (кеше гәүдәсе турында). *Илдарны күрмәмешкә салышып, [әби] үзе кебек кәкрәеп килгән бер әбигә үзе чыгарган гайбәтне тагы да әшәкерәк төстә сөйләргә кереште.* Г. Гобәй.

2. *сөйл.* Авышу, янтаю. [*Немец танкы*] *бөтенләй кәкрәеп, җиргә сеңеп бара: тиздән сазлык аны бөтенләй йотачак.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч. гади с.* Үлү, вафат булу. [*Фәтхулла*] *үзенең дә, менә шушы әт кебек, тиздән кәкрәясен сизде һәм, чинап үлеп ятkан эткә ачу белән тибеп, тиз генә китеп барды.* Г. Иделле. [*Әхмәди:*] *Сугышта кәкрәеп калмасам, зур командир булмыйча авылга аяк та басмас идем.* Г. Бәширов.

КӘКСЕЛДӘҮ *ф. диал.* Сәлперәю; хәлсезләнү. *Кәкселдәп ятy.*

КӘКСҮ *ф. диал. к.* кәкселдәү. — *Әй, кәксегән нәрсә, әллә кая барырлыгың калмаган инде.* С. Кудаш.

КӘКШЕТҮ *ф. сөйл.* Каклау, киптерү. [*Миңнулла:*] *Былач [власть] кешеләрен ике багана арасына кәкшетергә әлярләр.* И. Гази.

КӘКШӘЮ *ф. сөйл. к.* кәкшү. *Кәкшәйгән сары йөзле бер абзый, радиола янына берәүне дә китермичә, команда булганны көтеп тора.* Г. Ахунов.

КӘКШҮ *ф. сөйл.* Каклану, кибү.

КӘКҮК *и. сөйл. к.* кәккүк I. *Әллә кайда сайрый сандугачлар, әллә кайда кәкүк кычкыра.* Ә. Ерикәй. *Кычкырма, кәкүк, тирәктә, Тавышың моңлы бигрәк тә.* М. Фәйзи.

КӘЛАМ *и. иск.* Сүз, сөйләм. *Кәламнән әүвәл сәлам кирәк.* Мәкаль.

◇ **Кәламе хикмәт** *иск.* — хикмәтле сүз. **Кәламе шәриф** *дини* — коръән; изге сүз. [*Хизбулла:*] *Алла тәгалә кәламе шәрифендә әйткән: барлык мөэминмөселманнар, оешыгыз,* [*дип*]. К. Нәҗми.

КӘЛИГӘ *и. диал.* Гәрәнкә.

Кәлигә шалкан — *к.* кәлигә.

КӘЛИМӘ *и. иск.* Сүз. [*Йосыф:*] *Менә син шикләнгән сүзнең алдына „мой“ яки „моя“ дигән кәлимәне куеп кара.* Ф. Әмирхан. *„Чеңләшә“ кәлимәсе безнең бик иске лөгатебез булырга кирәк.* Г. Тукай.

КӘЛИСӘ *и. иск. к.* чиркәү. *Тау буена тезелеп утырган Ослан* [*авылының*] *матур-матур йортлары, кәлисәсе Иделгә - - - матурлык бирмәктә иде.* Ш. Мөхәммәдев.

КӘЛПӘК *и.* Самовар торбасына кидерелә һәм чәйнек кую, күмер салу өчен хезмәт итә торган җайланма. [*Рәйханның*] *кулында кайнар үтүк, - - -* [*аны*] *китереп, өстәлдә яткан самовар кәлпәге өстенә куя.* Н. Исәнбәт. *Башмак эченнән, шылтырап, самовар кәлпәге килеп төште.* М. Әмир.

КӘЛТӘ *и.* 1. Тәне вак мөгез тәнкәләр белән капланган, сузынкы гәүдәле, озын койрыклы, зур булмаган сөйрәлүче хайван. *Кәлтә коры җирләрдә яши һәм бөтен гомерен җир өстендә үткәрә.* Зоология.

2. *с. мәгъ. диал.* Кыска, көтек. *Киңәш белән текән тун кәлтә булмый.* Мәкаль.

Кәлтә елан(ы) — 1) *к.* кәлтә. *Аның аяк астыннан, боргаланып, кәлтә еланнар шуышып уза, үлән арасында кечкенә бакалар сикерешә.* Г. Бәширов; 2) *күч.* мәкерле, хәйләкәр, усал кеше турында. [*Басарый:*] *Кара, кара, тонган күз, кайчан кул салдым?* [*Гайнавал:*] *Качкан чагында. Ах, син, кәлтә елан.* Т. Гыйззәт.

КӘЛТӘФИ *с. сөйл.* Фырт, тәти. [*Арслан:*] *Кәлтәфи егет булгансың икән син хәзер.* Ш. Маннур.

КӘЛЧӘК *и. зоол.* Себер елгаларында яши торган балык; *русчасы:* чехонь.

КӘЛШӘ *и.* Чабып алганнан соң яңадан үсеп чыккан иген яки үлән; курпы. *Болындагы тәмле куе кәлшә белән, басулардагы киң иркенлек белән тәмам туенып-рәхәтләнеп, ашыкмыйча-элсерәмичә генә көтү кайтты.* Р. Төхфәтуллин.

КӘЛӘВӘ *и.* Майда пешерелгән камырга кайнатылган балны яки шикәр комын сеңдереп әзерләнә торган мамык сыман ашамлык. *Кәләвәне формаларга салмыйча, тәлинкә белән генә бирергә дә мөмкин.* Хал. ашлары. — *Мине җырлатып, кәләвә ашарга бер тиен, ике тиен акча бирә торган булганнар.* Г. Камал.

КӘЛӘВӘЧЕ *и.* Кәләвә пешерүче оста. *Анда кәләвәче Галинең шул яр эченә чокып ясалган куышы күренә.* Н. Исәнбәт.

КӘЛӘПҮШ *и.* Хәтфәдән тегелгән баш киеме; түбәтәйнең бер төре (гадәттә бүрек эченнән кияләр). *Әни бер дә армый-талмый байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.* Г. Тукай. *Галләметдин ашыкмыйча гына бүреген салып, аның эчендәге яшькелт шомарган хәтфә кәләпүшне башына каплады.* Ш. Камал.

КӘЛӘПҮШЧЕ *и. иск.* Кәләпүш тегә торган һөнәрче, кәләпүш тегүче. *Безнең Насыйри Казан шәһәрендә, татар бистәсендә, ягъни толчокчы, читекче, кәләпүшче, сөякчеләр арасында тора иде.* Ж. Вәлиди.

КӘЛӘШ *и.* Кияүгә чыгарга килешенгән кыз, ярәшелгән кыз; яңа гына кияүгә чыккан хатын-кыз. *Яшь кара айгырны хәзер өйдә генә асрыйм, солы күп, симерсен, дим, билгеле бит: кәләшкә йөрергә шәп ат кирәк.* Г. Ибраһимов. *Шундый иртә яшь кәләш кочагыннан торып йөрергә ни пычагым калгандыр аңа.* Ә. Еники.

Кәләш әйттерү — кыз ярәшү.

КӘЛӘШЛЕККӘ *рәв.* Кәләш итеп, хатын итеп (алу, сорау һ. б.). [*Хөснетдин:*] *Тик бары минем Камилә сеңелкәшне кәләшлеккә алу уйларыгызны бөтенләй башыгыздан чыгарып ташлагыз.* Ш. Камал.

КӘЛҮ *ф. иск.* „Килү“ фигыленең борынгы формасы. *И гүзәл, кәл каршыма, кәл.* Г. Тукай.

КӘЛҖЕМӘ *и.* 1. Бәрәнгедән бик калын коймак сыман итеп пешерелгән ашамлык. *Егет, алабута күмәче һәм черек бәрәңге кәлҗемәсе ашап, кырларда бодай үстерде.* А. Гыйләҗев.

2. *диал.* Бөккән (эченә бәрәңге, кабак һ. б. ш. салып пешерелә). *Бәдри ишектән килеп чыкты да кулындагы бәрәңге кәлҗемәсен бүлеп-бүлеп малайларга өләште.* И. Гази. *Яңа гына мичтән җылынып чыккан вак бәлешләр, юачалар, кәлҗемәләр, салкыннан кергән кортлы май белән кәрәзле бал да килеп утырды.* М. Гали.

3. *күч. ирон.* Начар башкарылган эш; начар эшләнгән әйбер (күбрәк тәрҗемә турында). *Мондый хикмәт кәлҗемәләр чыга әле дә, Укучыбыз шуңаргамы мохтаҗ әллә?* З. Мансур.

КӘМАЛ *с. иск.* Камил, тулы. *Җәмилә бу сүзләрне ишетеп, кәмал дәрәҗә оялып „уф!“ дип җибәрде дә, күзеннән ике бөртек яшь бит өстенә тәгәрәп төште.* М. Гафури. || *и. мәгъ.* Камиллек; тулылык. *Һәр кәмалның бер зәвалы бар.* Мәкаль.

КӘМАЛӘТ *и. иск.* Камиллек, камил булганлык. *Мин дә бу мәкаләдә шундый кешеләрнең берсенең әүсаф* [*сыйфатларын*] *һәм кәмаләтен санап, сезне хәйранга калдырмакчы булам.* Г. Тукай. *Кәмаләтең бөек синең, Өммекәмал.* Ш. Бабич.

КӘМАНЧА *и.* 1. *иск.* Смычок, скрипка сызгычы.

2. Кайбер көнчыгыш халыкларында скрипканың бер төре.

КӘМИТ *и.* 1. *иск. сөйл.* Цирк. [*Гафифә:*] *Әллә син дә кәмиттә* [*паяц*] *булмакчы буласыңмы?* Г. Камал. *Теге минем җылынырга кергән ишәгем бик кызык кына итеп, кәмиттә өйрәткән ат шикелле чүмәшеп, бер урындыкка утырды имеш.* Г. Тукай. || Цирк бинасы. *Яңа такталардан корыштырган, зур гына каралты сымак кәмитнең нигезеннән алып түбәсенә кадәр күз камаштыргыч буяулы сурәтләр!* Ә. Фәйзи.

2. *иск. гади с.* Спектакль, концерт, гомумән нинди дә булса тамаша. [*Корбангали:*] *Кәмитләр ясап акча җыйнарга керешкәннәрмени инде?* Ш. Камал. *Кәмитләр авыл сабан туйларының күрке булган.* Соц. Тат.

3. *күч. сөйл.* Көлке, көлкеле тамаша. [*Нигъмәт:*] *Суд бөтенләй бер кәмиткә әйләнеп китте.* Г. Камал.

Кәмит уйнау *сөйл.* — спектакльдә уйнау, концертта катнашу; артист булу. [*Хажи Җәләлгә:*] *Тик сиңа кәмит уйнап йөрүне ташларга кирәк булыр.* Ш. Камал.

КӘМИТЛЕК *и.* Артык ясалма кыланышлар, үтә кыланчыклык; артык көлкелелек; шамакайлык. *Дсәрдәге кимчелекләрдән тагын урыны-урыны белән кәмитлеккә, шаржга бирелүне әйтергә кирәк.* М. Җәлил.

КӘМИТСЕНҮ *ф.* Кәмит (3 мәгъ.), көлке дип табу. *Хосусан, Гариф кәмитсенгән шикелле елмаеп ук тора иде.* Ш. Камал.

КӘМИТЧЕ *и. иск.* Кәмиттә (1 мәгъ.) уйнаучы, кәмит артисты.

КӘМИТЧЕЛЕК *и.* 1. *к.* кәмитлек. *Аерым урыннарда цирк клоуннарын хәтерләтә торган кәмитчелек кенә бу матурлыкны боза.* М. Җәлил. *Аңача Россия театрларында куелып йөртелгән әсәрләр кәмитчелек*[*кә*] *корылган булып, Чехов әнә шул кәмитчелеккә каршы чыкты.* Г. Нигъмәти.

2. *сөйл.* Спектакль кую эше, тамаша башкару эше. *Ләкин гомеремнең кәмитчелектә үтүенә мин аз гына да үкенмим.* Каз. утл.

КӘМӘ *и. диал. к.* көймә. *Без нурлы ай яктысында, „Ак күл“ күле буйлап, әкрен генә кәмә белән түбән таба йөзеп килә идек.* М. Җәлил.

КӘМӘЛ *и.* Нинди дә булса корылманың, предметның нигез өлеше; каркас. *Дамбаның кәмәле бар инде: хәтта өстеннән - - - автобуслар йөри, тукталышлар бар.* А. Гыйләҗев.

КӘМӘР *и. иск.* Билбау, пояс. *Үзе дә сизмәстән, чишелгән изүен каплый, чәчен, билендәге кәмәрен төзәтә.* Г. Ибраһимов. *Зариф йөрәгенә чыдый алмыйча елмайды, нечкә кәмәр белән буган ак күлмәгенең чигүле якасын ычкындырып җибәрде.* Г. Әпсәләмов.

КӘМӘШ *и. сөйл.* Артык әһәмиятле, кыйммәтле саналмаган берәр зат, предмет. *Ул бит күпне теләми: бер аты булса, күп ашамый торган бер сыер кәмәше.* И. Гази. *Җәен алабуталар, кышын кар өемнәре белән чорнала торган бер өй кәмәшебез бар инде.* Г. Толымбай.

КӘН *и. иск.* Шахта, рудник.

КӘНДЕ *и. иск. кит.* Үз, үзе. *Рус фабрикант вә сәүдәгәрләре кәнде --- малларыны бөек файдалар илә сатачаклар имеш.* Г. Тукай. *Галиәкбәр агай кәндесе кеби ике юан корсаклы татар илә бөтен буфетны [билән алган].* Ш. Мөхәммәдев.

КӘНДИ *и.* Кечкенә аш савыты, кечкенә коштабак. *Аңа ике дөнья бер кәнди.* Әйтем. [*Хәлим*] *агач кәнди алып, күршегә катык сораргә кереп китте.* И. Гази.

КӘНДИЛ *и. сөйл. к.* кандил. *Идел өстен алып торган Нурлы кәндил, шәм Казан.* Н. Исәнбәт.

КӘНИЗӘК *и. иск.* Хан сараена яисә ханның берәр якынына хезмәткә алынган кол хатын яки кыз. *Матур хатын-кызларны кәнизәк ясау дәрте хәзрәткә дә, җиткән шәкертләргә дә бик ләззәтле булып күренде.* М. Гафури. [*Патша кызының*] *ике ягында уникешәрдән барлыгы кырык сигез кәнизәк кызлары йөридер.* Әкият.

КӘНИТИЛ *и.* 1. Чигү эшендә кулланыла торган, алтын яки көмеш йөгертелгән нечкә генә чыбыклардан үрелгән укалы җеп. *Көмеш кәнитил.*

2. *күч. сөйл.* Катлаулы вакыйга, четерекле эш. [*Халикъ:*] *Нәсимә кыздырмаса гына ярар иде. Ни булса да берәр кәнитил булмый калмый, иллә-мәгәр булырга тиеш.* Ш. Камал. || Мәшәкать, мәшәкатьле эш. [*Кулаев:*] *Автомобиль дигәч тә, аның кәнитиле бик күп.* Ш. Камал.

КӘНИТИЛЛЕ *с.* Кәнитил белән бизәлгән. [*Айсылуның*] *башында кәнитилле, укалы тар калфак.* Н. Исәнбәт. [*Җиһанша*], *яка читләрен чиккән кызыл күлмәгенең ак сәдәфле изүен як-якка чишеп җибәреп, кәнитилле кәләпүшен кыңгыр салып тора.* Ф. Сәйфи-Казанлы. || *күч. сөйл.* Четерекле.

КӘНСИР *и. сөйл. к.* консерв. [*Ибрай:*] *Китереп ач шунда кәнсир заводы — помидор кирәкме, кыяр кирәкме, кызыл борыч кирәкме, үстереп өлгертәбез.* М. Әмир.

КӘНСӘЛӘР *и. сөйл. к.* канцелярия. [*Зәкия:*] *Ул турыда кәнсәләрдә сөйләшмиләр.* Р. Ишморат. [*Гарифуллин:*] *Кичә Борһан кәнсәләрдә мактап утырган булды.* М. Шәрифуллин.

КӘНТИ *и. диал. к.* кәнди. *Малайлар анда зур кәнти яисә кувшин тотып җиләк җыярга баруны үзләре өчен бик зур саныйлар.* С. Җәләл.

КӘНТӘЙ *и.* 1. Ана әт. [*Ассистент:*] *Ә тегесе, кәнтәе, Шәфика Сабировна әте.* А. Расих. [*Капитал дөньясында*] *берәр кәнтәй балаласа, махсус нянька тәгаен ителә.* М. Гафури.

2. *күч. гади с. тирг.* Ирләр белән чуала торган хатын-кыз. [*Абыстай:*] *Шуны мактавыгызны җенем сөймәс, аның матурлыгыннан тун тегеп булмый. Бер кәнтәй булыр шунда.* С. Рафиков. [*Мәликә Шәмгунга:*] *Ул кәнтәе синең тирәдә чытлыклана икән әле.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Ирләр белән чуала торган. *Борчылуларының төбе — Садыйкның анда, чит җирдә, берәр кәнтәй хатын белән бәйләнеп китү куркынычы икән.* Г. Ибраһимов.

КӘНТӘЙЛЕК *и. гади с.* Чытлыклык; үзен кәнтәйләрчә (2 мәгъ.) тоту; эшәкелек.

КӘНТӘЙЛӘНҮ *ф. гади с.* Чытлыклану, кемгә дә булса ярарга тырышу; эшәкелеккә бару. — *Тешсез карчыктан өшкертеп пычагым да булмас, дидем. Кәнтәйләнеп үз сүзеңне иткән булдың.* М. Әмир.

КӘНТӘК *с. диал.* Тәбәнәк, кыска. [*Егет:*] *Кара әнә [каеннарны]. Саратов якларындагылар түгел инде: үзләре кәнтәк, үзләре нәзек.* М. Хөсәен.

КӘНФИТ *и. сөйл. к.* конфет. [*Хәйретдин:*] *Менә, бер итәк... кәнфит, прәннек, чикләвек, йөзем, җимеш — бары да бар.* Ф. Бурнаш.

КӘНФИТЛӘНҮ *ф. гади с.* Кыланчыклану, төчеләнү. — *Берәүләргә ялынып сорасалар да әләкми, ә син китереп биргәнне алмыйча кәнфитләнәсең.* Г. Бәширов. [*Гәрәй:*] *Таләп итәсе урынга кәнфитләнеп маташмагыз.* А. Гыйләҗев.

КӘНӘ I *терк. иск. кит.* Янә, тагын. *Вә кәнә үзегезнең җибәргән әманәтегез сәламәт тапшырылды.* Г. Тукай.

КӘНӘ II: **кәнә үләне (уты)** — орлыгыннан касторка мае алына торган үлән үсемлек; *русчасы:* клещевина.

КӘНӘРИ *и. сөйл. к.* кенәри. [*Татарларда*] *өй кошларын асраучылар бик аз: мәсәлән, кәнәри, сандугач кебек сайрый торган кошлар асраштырганлыйлар.* К. Насыйри.

КӘНӘФИ *и. иск.* Зур булмаган диван. *Зыя, кәнәфигә кырын ятканда хәлдә, кулындагы китапны актармакта иде.* Г. Ибраһимов. *Сөләйман, --- калын атлас белән тышланган кәнәфигә утырып, --- карта уйнап утырган кешеләргә күзен төшерде.* К. Тинчурин.

КӘПЕРЕНҮ *ф. сөйл. к.* кәпәренү. *Хәбибулла, --- хәзер замана безнеке, дип кәперенде.* Ш. Хөсәенов.

КӘ'П-КӘКРЕ *с.* 1. *Арт. дәр. к.* кәкре. *Борны кәпкәкре бөгелгәндер тәмам кармак кеби; Төз түгел куллар, аяклар да, ботак-тармак кеби.* Г. Тукай.

2. *күч.* Бөтенләй дөрес булмаган, бөтенләй ялган. *Тор, рәхәтлән, кәп-кәкрене туры дисәң, Истибдатның [деспотизмның] намусына тукынмасаң!* Г. Тукай.

КӘПРӘЮ *ф.* Үз-үзеңне артык әре тоту; масаю; кукраю, һавалану. *Юкка кәпрәйгән — вакытсыз кәкрәйгән.* Мәкаль. *Бибисара апаның көннәр буе сөйләшмичә кәпрәеп утырган вакытлары да булды.* Г. Минский.

КӘПӘРЕНҮ *ф. к.* кәпрәю. — *Мин аның урынында булсам, валлаһи, кәпәренми түзә алмас идем.* Ш. Маннур. *Хатын, председатель Вәлиевкә барып, Шәвәлине кичерүне сорагач, теге, мәсьәләне кабыргасы белән куябыз, дип кәпәренде.* С. Рафиков.

КӘПӘЧ *и. диал. к.* кәләпүш. *Ул, учитель булса да, кәпәч кигән.* Г. Тукай. || Гомумән нинди дә булса баш киеме (гадәттә кимсетү төсмере бирә). — *Салкыннар җитте бит, малай, син бу кәпәчеңне бүтән нәрсә белән алыштырыр идең.* Ф. Хөсни.

◇ **Кәпәч борын** — дуңгыз. *Дуңгызлар өчен абзарны юлның аръягына, тау итәгенә чыгарып салдырырга кирәк булыр. Кәпәч борыннар тик тауны сөрсеннәр.* Ә. Еники.

КӘПӘЧЛӘГӘН *ы. гади с.* Үкенүне, канәгатьсезлекне һ. б. ш. хисләрне белдерә. [*Кирамов:*] *Пьесаның чын исеме дә „Галимнәр белән наданнар“ түгел, ә „На чужом пиру похмелье“. Кәпәчләгән!* Н. Исәнбәт.

КӘРАМӘТ *и. иск.* Дини күрәшләр яки хорафатлар буенча: изгеләр генә эшли ала дип карала торган эш. *Ишан, иң түрдә китап тотып, борынгы әүлияларның --- кәрамәтләрен сөйләп утыра.* М. Гафури. *Былтыр камчылы ишан үзенең хәстә асравын өшкереп, кәрамәте вә шифалы төкреге белән мискинәне сәламәтләндерде.* Г. Тукай.

◇ **Кәрамәт иясе** — *к.* кәрамәтче. *Йөзләре дә, кулларыда аеруча нәфис булып күренгән бу кызлар аңа гаҗәеп бер кәрамәт иясе булып тоела башладылар.* М. Әмир.

КӘРАМӘТЛЕ *с. иск.* Дини карашлар яки хорафатлар буенча: кеше эшли алмаган эшләрне башкара торган; изге эшләр эшли ала торган. *Шулай итеп, кәрамәтле нәселдән килгән данлыклы Җәләлетдин мулланың намаз урынында үз күзе алдында - - - беренче мәртәбә музыка тавышы ишетелә.* Г. Ибраһимов.

КӘРАМӘТЧЕ *и. иск.* Дини карашлар яки хорафатлар буенча: төрле кәрамәтләр эшли ала торган кеше. *Күрәзәләре, сихерчеләре, кәрамәтчеләре, йолдызга вә башка нәрсәләргә карап һәртөрле серләрне сөйләүчеләре бик күп булып, һәртөрле юллар илә надан халыкны шаштырып торалар.* Шура.

КӘРБӘЗ *и. иск.* Купшы кеше, франт.

КӘРБӘЗЛЕК *и. иск.* Купшылык, франтлык. [*Карының*] *киенүендә ниндидер үзенә күрә элегантлык, кәрбәзлек, хәрәкәтендә салмак сынлылык, әмма эшләпә киюендә аерым бер чибәрлек бар иде.* Б. Урманче.

КӘРБӘН *с. сөйл.* Шактый зур, зур гына. *Хәзрәт үзе сөйлгән арада тик тормады, үрдәкне юып, эчләрен тазартып кискәләде дә, кәрбән генә бер корымлы кәстрүлгә салып, тимер мич өстенә куйды.* Ш. Маннур.

КӘРВАН *и.* 1. Чүлләрдә, далаларда кешеләр озатып бара торган, аркаларына йөкләр салынган хайваннар төркеме. *Эт өрер, кәрван барыр.* Әйтем. *Исәр-исмәс җил белән әкрен генә тузанланып, тынгысызланып торган юл да, шул юл буйлап ялкау гына атлаучы дөяләр кәрваны да тынлыкны һәм хәрәкәтсезлекне боза алмыйлар иде.* Ә. Фәйзи.

2. Кем яки нәрсәләрнең дә булса хәрәкәт итүче төркеме. *Ул үзе, Себер сахралары буенча качаклар кәрваны белән агылып барганда, бер яшь, матур татар прапорщигына гашыйк була.* Г. Ибраһимов. *Алар, кыр казлары кебек тезелеп, Иделнең уңъяк яры буйлап боз өстеннән баручы юлаучылар кәрваны артыннан куып җиттеләр.* М. Гали.

КӘРВАНБАШ *и.* Кәрванны алып баручы, кәрван башлыгы. *Бу шәһәрдән ерак-ерак илләргә кәрван чыгып бара икән күп мал белән. Малай кәрванбашка бара.* Әкият.

КӘРВАНСАРАЙ *и.* Кавказда һәм Азиядә кәрван юлларында кәрван кереп куна торган йорт. [*Әбүгалисина:*] *Анда кәрвансарай, монда базар.* Н. Исәнбәт.

КӘРВАНЧЫ *и.* Кәрванны озатып баручы кеше, кәрван йөртүче. *Кәрванчылар бик күп михнәттән соң Иран туфрагына чыкканнар.* Ф. Бурнаш.

КӘРЕШКӘ *и. сөйл. к.* кәрәшкә. *Агыйделнең буе гел кәрешкә, Башларында тора күк чәчкә.* Җыр. *Кәрешкә, мәтрүшкә, кәккүк чәчәкләре - - - белән чуарланган, әле чабылып өлгермәгән болынның хуш исле җиләс һавасына туйганчы иркәләндек.* М. Әмир.

КӘРЗИН *и.* 1. Нәрсәне дә булса салып йөртү яки саклау өчен тал чыбыкларыннан, камыштан, юка дранчалардан һ. б. үреп ясалган савыт. *Нәкъ шул вакытта ишекләренең берсендә кулына кечкенә генә кәрзин тоткан алты-җиде яшьлек бер кыз бала күренде.* Г. Гобәй. *Аргы очтан, көнтә башларына юылган керләр салынган кәрзиннәр элеп, бер кыз килә.* Ә. Фәйзи.

2. *бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан булган үсемлекләрдә чәчәк төркеме төре.

КӘРЗИНКӘ *и. сөйл. к.* кәрзин. [*Сәхип:*] *Җомагыл агай, безгә* [*бер*] *кәрзинкә пиво китер.* Г. Ибраһимов. [*Гарифә:*] *Беркөнне югары урамга чыкканда күргән идем, кулына кәрзинкә күтәреп, бәрәңге алып йөриләр иде.* Г. Камал.

КӘРКЕДӘН, КӘРКӘДӘН *и. иск. к.* мөгезборын. [*Арыслан*], *юлбарыс, кәркедән, каплан, фил, кабан дуңгызы кебиләрне каршына чакырып, „Сез Бүрене ничек дип беләсез?“ — дип сорашты.* Г. Тукай.

КӘРКЕШ *и. диал. к.* киндерә. *Ялкау кәркешен ураганчы, караңгы төн таң аткан.* Мәкаль. *Алтынланган чабатаңның ефәк мәллә кәркеше?* Җыр.

КӘРЛӘ *и.* 1. Нормаль булмаган, артык тәбәнәк буйлы кеше. *Гипофиз үсеп җитә алмаса, баланың үсүе туктала һәм ул кәрлә булып кала.* Анатомия. || Гомумән кечкенә буйлы кеше. [*Нуркәй:*] *Янында бөтенләй кәрлә булып калдым.* Һ. Такташ.

2. Әкиятләрдә: бик кечкенә фантастик зат. *Ташказар ишекне ачуга, батыраеп, килеп керә бер кәрлә.* Әкият.

3. *с. мәгъ.* Кечкенә, бик кечкенә. *Ишек артыннан кәрлә көчек өргән тавыш ишетелә.* А. Әхмәт. *Эчке зәһәреннән нишләргә белмичә ярсып торган бу кәрлә кешене бер сугуга җиргә сеңдерүнең рәхәтен алдан ук сизеп, йодрыклары үзеннән-үзе йомарлана башлаган иде.* Г. Бәширов. || Кечкенә, әһәмиятсез. *Олы уйлар төртеп уята да, кәрлә эшемне кочаклап йокыга китәм.* Р. Фәйзуллин.

Кәрлә агач — бик кечкенә агач. **Кәрлә йолдыз** *астр.* — яктыртучанлыгы бик көчсез булган йолдыз.

КӘРЛӘЧ *и. бот.* Сабагы һәм яфраклары сусыл декоратив үлән үсемлек; сахра борычы; *русчасы:* очиток. *Зәһәр кәрләч.* □ *Нарат урманнары янындагы зур аланлыклар кайвакыт, таш түшәлгән киң юл кебек, сусыл түгәрәк кәрләч төлгәшләре белән капланган булалар.* Робинзон әзл.

КӘРНИЗ *и.* 1. Бина стенасының иң югарыгы өлешендә стенаны яңгырдан саклау өчен ясалган чыгынты; тәрәзә, ишек өстенә ясалган чыгынты. *Бакча әчендә госпиталь, Кәрнизләре челтәрле.* Ф. Кәрим. *Моннан биш ел әүвәл - - - бу йорт*[*ның*] *- - - тәрәзә пыялалары болай кырылмаган, аның кәрнизләре, почмаклары болай ишелмәгән, җимерелгәләп бетмәгән иде.* Ф. Әмирхан.

2. Штор, пәрдә элү өчен тәрәзә яки ишек өстенә беркетелә торган аркылы борыс. *Гөлсем апа моңарчы, күрәсең, күз төшмәү сәбәпледер, ягылмыйча тәрәзә өсләрендә эленеп калган кәрнизләрне күрде.* Г. Гобәй.

КӘРРӘ *и. иск.* Мәртәбә, тапкыр. *Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син, һәр ишектән сөрде углыңны мәхәббәт сакчысы.* Г. Тукай. *Рәт белми йөргәнеңнән — мең кәррә артык җаның чыгып, җир астына кереп ятмак.* М. Гафури.

КӘРТ *и. сөйл.* Карта, уен картасы. *Кәрт уйнау.*

КӘРТЛЕ *и. сөйл.* Карта уены. *Мостафа мулла, йөзе кара, кәртле уйнап оттырды малын.* Бәет.

КӘРТЧЕ *и. сөйл.* Карта уйнарга яратучы, карта уены белән мавыгучы. *Домино уйнаучыларны кәртчеләр шелтәлиләр.* Кызыл таң.

КӘРЧӘМӘ *и.* Озак тору аркасында бик нык әчегән катык. *Йокы кәрчемә кебек: биш сәгать әчендә ойый, алты сәгатьтә ачый.* Мәкаль.

КӘРЧӘ-МӘРЧӘ *җый. и. диал. к.* кәкер-чөкер. *Марзия абыстай, кәрчә-мәрчәләрен хәзерләп, чәй янын рәтләде дә күптән ук кайнатып куелган самоварын китереп куйды.* Г. Толымбай.

КӘРӘЗ *и.* Бал туплау, күкәй салу өчен бал кортлары яки шөпшәләр тарафыннан тигез рәтләр итеп балавыздан ясалган күзәнәкләр. *Бөтен ояда бердәнбер булган ана корт кәрәз күзәнәге саен йомырка салып йөри.* А. Әхмәт.

КӘРӘЗЛЕ: кәрәзле бал — кәрәзеннән суыртып алынмаган бал, кәрәзе белән алынган бал. *Габденнасыйр табаклы балдан кул кисәге кадәр кәрәзле балны кисеп, Шөгаепнең кулына тоттырды.* М. Гали. [*Нәгыймә*] *кәрәзле бал белән ак күмәч куйды.* Г. Ибраһимов.

КӘРӘЗЛӘНҮ *ф. сөйл.* Кечкенә куышлыклар барлыкка килү, кәрәз кебек тишекләр ясалу. *Тамчылар*

тамдылар. Өй түбәләреннән бүрек-бүрек булып кәрәзләнгән карлар кубып төште. Р. Ильяс.

КӘРӘКӘ *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан зур булмаган балык, табан балыгы; *русчасы:* карась.

Кәрәкә балыгы — *к.* кәрәкә. — *Тик, хәерсез, ауга кәрәкә балыгы гына эләгә.* М. Хәсәнов.

КӘРӘМӘТ *и. сөйл. к.* кәрамәт.

Кәрәмәт шәп — бик шәп. [*Гөлбикә*], *бик моңаеп, башын чайкап, сыерны кызганды: „Кәрәмәт шәп сыерыбыз иде“.* Г. Иделле.

КӘРӘЧИН *и. сөйл. к.* керосин. — *Кибеткә барасым, кәрәчин алып кайтасым бар, дигән иде, шунда киткәндәр, — диде Гайниямал.* Ә. Фәйзи.

КӘРӘШКӘ *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык үсемлек, виканың бер төре. [*Даланың*] *табигый үсемлекләре --- төрле үләннәрдән һәм эт әчәгесе, кәрәшкә үләне белән чорналган әремнәрдән тора.* СССР физ. геогр.

КӘРҖИН *и. диал. к.* кәрзин. [*Кыз:*] *Алайса --- әнә шул кәржинне генә алып бирсәнә.* И. Гази.

КӘС *и.* 1. Туфракның үләннәр тамыр җибәреп, үсеп утыра торган өске катлавы. *Гомер-гомергә сөрелмәгән калдаулыкларның каты чирәмле кәсләрен зур сабан төрәннәре белән кубарып салуны үз күзләре белән күргәч, бу ике кеше, бер-берсенә карашып, кәтып калдылар.* С. Рафиков.

2. Шул катлаудан кисеп алынган кисәк яки каерып ташланган катлам. *Шәйхәттар бабай, чи калган җирдә туктап, сабан төрәне каерып салган кәсләрне аягы белән буразнага сыпырып төшерде.* Г. Гобәй. *Калын-калын кәсләрдән әйбәтләп салынган балаган әче тактalар белән икегә бүленгән.* И. Туктар.

КӘСАФӘТ *и. иск. к.* кәсәфәт. [*Мөбарәкша:*] *Олуг тәңре үзе сакласын аларның кәсафәтеннән.* К. Нәҗми. *Хәрбилек кәсафәтләре бер дә күзгә бәрелми иде егеттә.* Р. Төхфәтуллин.

КӘСЕП *и.* Кеше даими шөгыльләнгән һәм яшәү чыганагы булган эш, хезмәт, шөгыль. *Бу авылның бөтен кәсебе урман кисү икән.* М. Гафури. *Без көтүне ташлап башка кәсепкә тотынгач та, озак елларга кадәр халык безне онытмады.* М. Гали. || Сәүдә, сәүдә эше. *Һәр атнаның дүшәмбесендә кайнап, шаулап тора торган зур базары һәм иген, мал, урман кәсебе аркасында күрше авыл халыкларын үзенә җыйган, атаклы байлары белән дан тоткан өлкән авылның --- мескен бер балчык өендә --- [алар] тыныч, шау-шусыз гына гомерләрен үткәрә булганнар.* Г. Ибраһимов.

Кәсеп итү — 1) нинди дә булса эш эшләп, берәр төрле шөгыль белән көн күрү. *Теләче буйлары инде алар гомер-гомергә, ата-бабадан шул тегүчелек белән кәсеп итеп киләләр.* М. Гали. *Бу бистә нугайлары, күбесенчә, бакчачылык белән кәсеп итә.* Г. Минский; 2) сәүдә итү, сәүдә эше белән шөгыльләнү. *Шуннан аны зур базарлы авылда тире-яры белән кәсеп итеп торучы Шәяхмәт дигән абзасы үзенә „тәрбиягә“ алган.* Ә. Еники. *Чегәннәргә очко бирә иде ул ат белән кәсеп итү эшендә.* М. Әмир.

КӘСЕПЛЕ *с. иск.* Кәсебе булган. *Кәсепле кеше.*

КӘСЕПЛӘНҮ *ф.* Нинди дә булса кәсеп белән шөгыльләнү, шул кәсеп белән көн күрү. *Читтә йөреп кәсепләнү.* □ [*Корбангали*] *йозагы җимерелгән әчкечләргә йозаклар юнәтеп кәсепләнә иде.* Ш. Камал.

КӘСЕПСЕЗ *и. иск.* Кәсебе булмаган; хезмәт урыны юк, эшсез. *Кәсепсез кеше.*

КӘСЕПСЕЗЛЕК *и. иск.* Кәсеп юклык, эш булмау; хезмәт урыны булмау. *Ярлылык, кәсепсезлек шулай иттереп хәерчеләрне бик яхшылап үзе китереп чыгара.* М. Гафури.

КӘСЕПТӘШ *и.* Кем белән дә булса бер үк кәсеп белән шөгыльләнүче кеше. | *с. мәгъ. Кәсептәш дуслар.*

КӘСЕПЧЕ *и.* 1. Яшәү өчен чыганак булып торган берәр һөнәр белән көн күрүче кеше. *Эш эзләп баручы приказчик, конторщик, мөгаллим, һөнәрчеләр, кәсепчеләр --- дүртенче класста бара.* И. Рәмиев. *Мин кәсепче булып йөри башладым.* Ш. Маннур.

2. *сөйл. хупл.* Нинди дә булса шәхси файда күзәтеп, рәсми булмаган берәр эш белән шөгыльләнүче кеше. *Җиңел табыш артыннан куып, урманнарыбызның яме, күрке булган шомырт агачын юкка чыгаручы кәсепчеләргә бернинди дә чара күрелми.* Соц. Тат.

КӘСЕР *и. сөйл. к.* кантар. — *Сул яктагы полосаның җире каты, төрле, әре кәсерләр белән тулган, ә уң яктагы колхоз җире йоп-йомшак, кәсерләр юк.* Г. Иделле.

КӘС-КӘС: кәс-кәс басып бару (атлау) — *к.* кәзкәз басып бару. *Кыз да артык кабаланмыйча кәс-кәс атлап кына килде.* А. Расих. [*Фирая*] *кәс-кәс басып ишеккә юнәлде.* И. Гази.

КӘСЛӘҮ *ф.* Кәс (2 мәгъ.) белән каплау, кәс салып нигыту (туфракны, ярларны һ. б. ш.).

КӘСРӘТ *и. иск.* Күп булу, күплек, муллык, артыклык.

КӘССАП *и. иск.* Мал суючы, хайван бугазлаучы; чалучы.

КӘСТРҮЛ *и.* Аш-су пешерү өчен гадәттә цилиндр формасындагы металл савыт. *Пылау пешерү өчен калын төпле яки чуен кәстрүл, я кечкенә казан кирәк.* Хал. ашлары.

КӘСТӘНӘ *и. иск. к.* каштан. *Кәстәнә агачы.* □ *Узыша пальмалар, Кәстәнә, анарлар.* Н. Арсланов.

КӘСӘ *и.* 1. *к.* касә. *Шуңа су салып, утта кайнатабыз да, беребез агач савыт, икенчебез әллә ничә җиреннән сыланып, бәйләнеп беткән кәсә белән чәй эчәбез.* Г. Ибраһимов. [*Бөркетбаев:*] *Мунчадан соң безнең өйгә кереп, бер-ике кәсә кымыз эчеп чыгыгыз.* И. Салахов.

2. Чәчәк таҗын саклау өчен аның астында аерым яки кушылып үскән яшел яфраклардан гыйбарәт булган чәчәк тирәлегенең бер өлеше. *Кәсә һәм таҗ икесе бергә чәчәк тирәлеге төзиләр.* Ботаника.

Кәсә яфракчыгы — чәчәк таҗын саклый торган бөжра тәшкил итүче яшел яфракчыкларның берсе. *Чәчәкнең тышкы ягында 4 яшел яфрак — кәсә яфракчыклары күренеп тора.* Ботаника.

КӘСӘРТКЕ *и. диал.* Кәлтә. *Елан өчкә өзелсә дә, кәсәрткелек хәле бар.* Әйтем.

КӘСӘФӘТ *и. сөйл.* Нинди дә булса эшнең яки күренешнең начар нәтиҗәсе, начар йогынтысы, шаукымы, зарары. [*Ярулла:*] *Председатель Гөлсем тирәсендә чуалгалады, шуның кәсәфәтедер.* Ф. Бурнаш. [*Шакир:*] *Ул заманның эшләү методлары бериш кешенең канына сеңеп беткән иде бит. Аның әле, уемча, кәсәфәте озакка тартылыр.* А. Расих.

КӘТАВЫЛ *и. иск.* Крепость коменданты.

КӘТЕР *и. сөйл. к.* каторга. [*Хәлим:*] *Ут төрткән өчен башны кәтер җибәрәләр.* И. Гази. — *Кәтер китсә китте, ләкин Залимханның башына җитеп китте.* Г Гобәй.

КӘТИРИНКӘ *и. иск.* Революциягә кадәр: Екатерина II нең рәсеме төшерелгән йөз сумлык акча. *Фәрхетдин абзагыз көннәрдән бер көнне кәтиринкәне әйбәтләп кенә төреп кесәсенә салып куяр да, түшне киерепләп, җырлый-җырлый Нәдергә кайтып китәр.* А. Расих.

КӘТЕРМӘЧ *и.* 1. *диал.* Солы онынан бармак калынлыгы итеп пешерелгән җәймә (ашамлык).

2. *сөйл. к.* сохари.

КӘТЛИТ *и. сөйл. к.* котлет. — *Юлга ашарга уникә кәтлит, икә алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, икә чебеш хәзерләдем.* Г. Камал.

КӘТМӘН *и. диал. к.* китмән. *Бала сүзе батмандай, килен сүзе кәтмәндәй.* Мәкаль.

КӘТТӘ *с. сөйл.* 1. Эре, һавалы, үзен артык әре тота торган. *Болай читтән карап торырга бик кәттә егетләр күренәләр.* М. Гафури. *Әмма Богдасар бик кәттә кеше, синең кебек ыбыр-чыбырның мәҗлесенә килергә теләмәс.* И. Гази. || Дәрәҗәле, абруйлы. *Казанның „Шәрык клубы"на шәһәребезнең „менә" дигән кәттә кешеләре җыелган иде.* Г. Тукай.

2. Шәп, бик яхшы. [*Фәйзулла:*] *Туктагыз әле, үзем табыйм әле шуңар* [*кушаматның*] *бер кәттәсен генә.* Ф. Бурнаш. — *Барысыннан да кәттәсе — әлеге моторлы көймәм.* М. Әмир. || Бик көчле, каты. *Кайчагында кәттә суыкларда күлмәкчән генә чормага менеп китә дә кызның хатларын рәттән барысын укып төшә.* А. Гыйләҗев.

КӘТҮК *и.* 1. Җеп яки тасма чорнау өчен ике як башы түгәрәктән гыйбарәт эче куыш агач үзәк. *Җеп кәтүге.* || Шундый үзәккә чорналган җеп күләме (алдында сан килә). — *Синең хатыңны алганнан бирле, Сәмига белән Мөдәррис көн саен әнвәрнең буен үлчиләр — бер кәтүк җебемне әрәм итеп бетерделәр.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч. ирон.* Кечкенә буйлы бала яки кеше турында. *Башка вакыт булса, бу акыллы, матур малайны Хәлим - - - берәр җир буе йөртеп килер иде, ә хәзер инде аның яныннан ачулы кычкырып узып китте: „Кит, кәтүк, хайван яныннан!"* Г. Гобәй.

3. *тех., физ.* Металл чыбык чорнау өчен стержень; металл чыбык чорналган эче куыш цилиндр. *Индукция кәтүге.* □ *Трансформатор кәтүкләре никадәр генә зур булмасын, аларны җыю зур осталык сорый.* Соц. Тат.

КӘФЕН *и.* 1. Үлгән кешеләрне төреп күмү өчен марля яки ак тукыма. *Ап-ак кәфенгә уралган Галимә апа — минем теге матур Галимә апам — җир астына төшеп югалды.* М. Гафури. *Ак кәфенгә төрелгән Галиулланы өйдән алып чыктылар да кабык өстенә салдылар.* И. Гази. || *сөйл.* Кәфенлек, кәфенлек материал. *Әллә кайчан ук* [*карчыкның*] *кәфене алып куелган.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Катлау, катлам (нигездә кар катлавы турында). *Ак кар кәфене.*

◇ **Кәфендәй агарыну** — ап-ак булу (йөз, бит турында). *Гали хәзрәтнең йөзе кәфендәй яман агарынды, бу соңгы сүз аның йөрәгенә ук булып кадалды.* Г. Ибраһимов.

КӘФЕНЛЕК *с.* 1. Кәфен өчен билгеләнгән. *Кәфенлек марля.* || *и. мәгъ.* Кәфен өчен билгеләнгән, хәзерләнгән материал. [*Бикбулат:*] *Миңа ун аршын кәфенлек җиткән.* Г. Бәширов.

КӘФЕНЛӘҮ *ф.* 1. *Төш юн. к.* кәфенләү.

2. *күч.* Каплану, каплап алыну (кар белән). *Елга боз астына кача, карт урман ак кар белән кәфенләнеп, тагы да картаярак төшкән шикелле күренә.* Г. Ибраһимов.

КӘФЕНЛӘҮ *ф.* Мәетне кәфенгә төрү. *Гайфи әфәнде мөселман лазаретында бер - - - төрек офицерының вафат булганын белдереп, шуны кәфенләп җирләү өчен мәҗлестән алты кеше сорады.* К. Нәҗми.

КӘФИЛ *и. иск.* Гарантия бирүче, гарантияләүче, ышаныч күрсәтүче. || *с. мәгъ.* Җитәрлек, җитә торган. *Күрер идең зур асыл таш ятканын, Мәңге баетырга кәфил шул тапканың.* Г. Тукай.

Кәфил булу — гарантия бирү; җаваплылыкны үз өстеңә алу; ышаныч күрсәтү. *Малыңа дошман булсаң — кәфил бул.* Мәкаль.

КӘЧЕРКӘ *и. диал. к.* йокылык.

КӘШЕМИР *и. сөйл. к.* кашемир. *Рәхиләнең өстендә зәңгәр путалы ак күлмәк, башында кәшемир яулык.* Э. Касыймов. *Икенче яктан Гөлҗиһан килә. Чуар кәшемир шәл ябынган.* М. Фәйзи.

КӘШЕФ *и. иск. кит.* Ачыш; уйлап табу, уйлап чыгару. *Бер адәм - - - аңа таба килде дә, - - - зур кәшефкә ирешкәндәй күтәрелү белән: „Д... туган, Зыя!" — дип кул бирде.* Г. Ибраһимов.

Кәшеф итү *иск.* — ачыш ясау, ачу; уйлап табу, уйлап чыгару. *Американы кәшеф иткән Колумблар, телеграф, телефоннарны иҗат иткән Эдисоннар - - - анадан туганда ук шулай мәгълүматлы булып тудылармы?* Ш. Мөхәммәдев. **Кәшеф итүче** *иск.* — уйлап табучы, уйлап чыгаручы; ачыш ясаучы. *Сине* [*электрны*] *кәшеф итүчеләр бу заманда Мөбарәк бер урын алды бу җиһанда.* М. Гафури.

КӘШЛӘКӘ *и.* Агачны әләктереп яр өчен бер башы ыргаклы таяк.

КӘШФИЯТ *и. иск. кит. к.* кәшеф. *Журналның мөндәриҗәтенең мисалларын күрмәк теләсәгез, „Йолдыз"ның фәнни кәшфиятен укыгыз.* Г. Тукай.

КӘШӘКХАНӘ *и. иск.* Мавзолей. *Хәзерге Башкортстанның район үзәге булган Чишмә авылы янындагы Тура-хан кәшәкханәсе XIV йөздә шул рәвешле салынган.* Каз. утл.

КӘШӘКӘ *и.* 1. Боз яки җир өстендә туп яисә алка сугудан гыйбарәт спорт уенында кулланыла торган кәкре башлы таяк; *русчасы:* клюшка. *Кәшәкә белән тупка сугу.*

2. Боз яки җир өстендә шундый таяк белән туп яки алка сугудан гыйбарәт спорт уены. *Ул, урамда кәшәкә сугып йөрүче бер өер малайга көч биреп, киңәш биреп тора иде.* М. Маликова.

Кәшәкә таяк — *к.* кәшәкә. *Билгеле җирдән кәкре башлы кәшәкә таякны алып, өйалды ишегенең эчтән салынган бастырыгын төшердем.* Ф. Хөсни. *Хәлимне — ир баланы — кәшәкә таяк, футбол, балык тоту, төннәрен ат сакларга йөрүләр үз эчләренә алып кереп китәләр.* Г. Гобәй.

КӘШӘЛӘНҮ *ф. диал.* Кубалаклану, киселү, купшаклану; бозылу. [*Габитнең*] *иреннәре, битләре язгы җилгә кәшәләнеп-кәшәләнеп ярылганнар.* Ф. Кәрим.

КӘШӘЛӘҮ I *ф. диал. к.* кәшәләнү.

КӘШӘЛӘҮ II *ф. диал.* Аралау, каккалап аерып алу; әләктереп алу. *Атнабай сүзеннән туктап, учакны рәтләде, чыбык белән кәшәләп, бер бәрәңгене тартып чыгарды.* Г. Ахунов.

КӘШӘНКӘ I *и. бот.* Кайбер үсемлекләрдә (мәсәлән, чикләвек агачында) җимешнең төбен тәшкил иткән яфраклардан гыйбарәт үсенте. *Чикләвек кәшәнкәсе.* □ [*Июль*] *шафран куакларына матур-матур кәшәнкәләр бүләк итте.* Г. Галиев.

КӘШӘНКӘ II *и. диал. к.* дучмак. [*Әни*] *сөт, йомырка кушып, бик тәмле итеп бәрәңге кәшәнкәсе салган икән. Бу кәшәнкә бик тәмле тоелды.* Г. Галиев.

КӘШӘТАЯК *и. сөйл. к.* кәшәкә. *Малае-кызы — һәммәсе бергә тау шуып, боз өстендә кәшәтаяк уйнап бергә аунап үскән балалар.* Г. Бәширов.

КӘҮСӘ *и.* Агач яки куакның җир өстеннән башлап очына кадәр ботаклар җибәрә торган өлеше, төп сабагы. *Юан кәүсәле, зонтик сыман ябалдашлы юкәләр, имәнәр арасыннан чыгып җитәрәк туктап, бераз ял итәргә уйладым.* А. Шамов. *Каеннарның, белдем, кәүсәләре Кала һаман ап-ак көенчә.* З. Мансур.

КӘҮСӘР *и.* 1. *иск. дини* Дини караш буенча: оҗмах чишмәсе суы, оҗмахтагы бик татлы су. *Төшемдә* [*оҗмах*] *эчен күрдем. Бер тарафта балдан вә сөттән гыйбарәт кәүсәр елгасы агып ята.* Г. Тукай.

2. *күч. шигъ. иск.* Берәр төрле татлы яки татлы булып тоелган әйбер турында. *Сылубикә, сылу туташ, кыз солтаны, Авызың зәмзәм, ирнең кәүсәр, тешең гәүһәр.* Ш. Бабич.

КӘҖӘ I *и.* 1. Куыш мөгезләләр семьялыгыннан сөт, мамык, ит өчен асрала торган, артык зур булмаган, аеры тояклы йорт хайваны. □ *Сөтсез торып булмас дип, Галиулла шул ук базардан кәҗә сатып алды.* И. Гази. *Кәҗәсе, аның юклыгыннан файдаланып, күптән кызыгып йөргән кәбестәләргә кунакка китте.* Һ. Такташ. || *с.-х.мәгъ.* Кәҗә тиресеннән ясалган; кәҗә тиресеннән тегелгән. *Ярты кәҗә туны киеп алып, Салынып төшкән җиңен сызганып, Поход маршларын җырлый-җырлый Махноларга каршы кузгалдык.* М. Җәлил.

2. *күч.* Карта яки домино уеннарының бер төре. *Шахтага төшмәгән көннәрендә үзләрен кая куярга белмәгән олы һәм акыллы гына кешеләр, юанмакчы булып, „подкидной", „кәҗә", „девятка", „алтмыш алты" --- кебек уеннарга биреләләр.* И. Туктар. || Шундый уенда оттырган кеше. *Доминоны бәрәләр. Бүлмәләр селкенеп тора. Аста да, өске катта да кычкырулар „кәҗәләр".* Кызыл Таң.

3. *күч. тирг.* Кире, начар яки шулай дип саналган кеше турында әйтелә. [*Сәрби:*] *Син ничек миңа кәҗә дисең, ә?* Ф. Бурнаш.

Кәҗә бәтие (бәрәне) — кәҗә баласы. *Ә идәндә, койрыгын чәнчеп, ишекле-түрле бозау белән кәҗә бәтиләре чабып йөри.* Г. Бәширов. *Габишләрнең бәрәңге бакчасына һәрвакыт әлмәш бабайларның кәҗә бәрәне кереп аптырата торган иде.* Ф. Кәрим. **Кәҗә гөмбәсе** *бот.* — эшләпәсе эре җыерчыклар белән капланган кыска сабаклы гөмбә; *русчасы:* сморчок. *Иртә яз, кар китү белән, дымлы урманнарда --- һәм шулай ук чокырларда, учак яккан урыннарда кәҗә гөмбәсе --- өлгерә.* Робинзон әзл. **Кәҗә имчәге** *бот.* — канәферсыманнар семьялыгыннан болында үсә торган һәм сабагының югарысы өлеше ябышкак булган үлән үсемлек; *русчасы:* смолёвка белая. **Кәҗә мамык** — кәҗә мамыгыннан әзерләнгән, бәйләнгән. [*Гыйльметдин:*] *Аякта күн итек, башта сибирский бүрек, муенда кәҗә мамык шарф булыр.* Ф. Бурнаш. **Кәҗә мөгезе** *бот.* — 1) кузаклылар семьялыгыннан яфраклары мәңге яшел җимеш агачы; *русчасы:* рожки. *Елга үзәннәрендә --- кәҗә мөгезе һәм тут агачлары үстерү өчен уңайлы шартлар бар.* Чит ил. экон. геогр.; 2) шул агачның төче җимеше. **Кәҗә мөгезе тропигы** *астр.* — җир шары өстендә экватордан 23°27′ көньякта булган уйланма түгәрәк; көньяк тропик. *Хөдәйдә порты артта калды. Кәҗә мөгезе тропигын да үттек.* Каз. утл. **Кәҗә сакаллы** — сакалы кәҗә сакалына охшаган, тар һәм озын сакаллы. *Тәбәнәк буйлы, кәҗә сакаллы бер татар килеп керде.* Ш. Усманов. **Кәҗә сакал** — 1) кемдә дә булса кәҗә сакалына охшаган сакал; очлаеп беткән озын сакал. *Миңнулла, кәҗә сакалын югары тырпайтып, кисәргә агач сайлый башлады.* И. Гази; 2) *бот. к.* кәҗәсакал. *Аның төбендә җәй көннәрендә шайтан таяклары, ат кузгалаклары, кәҗә сакаллары, тигәнәкләр, әремнәр һәм башка шуның кебек тупас үсемлекләр гөрләп үсеп торганнар булса кирәк.* А. Шамов; 3) *этн.* кара ышану буенча: урак урганда, киләчәктә дә уңыш мул булсын дип, бергә китереп төенләнеп калдырылган бер учма үсеп утырган иген. *Ызаннар белән телгәләнгән вак җирләрдә кайсы ауган, кайсы көздән төйнәлгән килеш утырып торган, юл читләрендәге маякларны хәтерләткән „кәҗә сакаллары" күренделәр.* С. Рафиков. **Кәҗә сукмагы** — урманда, тау битләрендә һ. б. ш. урыннарда терлек йөри торган тар гына сукмак. *Авылга җитәрәк сулга сугылып, вак урманлыкка керделәр дә кәҗә сукмагы белән Пжытконың мал көткән җиренә үк килеп чыктылар.* Ш. Маннур. **Кәҗә тәкәсе** — 1) ата җенестәге кәҗә. *Урамда бары тик кара сыргалы ике кәҗә тәкәсе сикерә-сикерә уйный.* Г. Әпсәләмов; 2) *күч. тирг.* хатын-кызлар белән шаярырга яратучы кеше турында. [*Нәсимә Халикъка:*] *Әй, карт кәҗә тәкәсе! --- Исең китте инде шул Мәдинәгә, авыз суың коры-ды хәтта.* Ш. Камал. **Кәҗә чәчәге (гөле)** *бот.* — *к.* кыркырый.

◇ **Кәҗә билеты** *иск.* — башка эшкә яки укырга керү хокукын бетереп, дәүләт хезмәтеннән яки уку йортыннан чыгару турында таныклык. *Атабаев белән бер үк вакытта „кәҗә билеты" алып чыккан Сәҗидәкәй нарсуд курьеры булып эшли иде.* Г. Иделле. **Кәҗә билеты бирү** *кимс.* — гомумән эштән, хезмәттән ирексезләп чыгару турында әйтелә. *Степанов дигән кеше аклар белән качып киткән иде. Шул кеше хәзер, кайтып, нинди юл беләндер, тегермәнгә мөдир булган. Бу кешегә кәҗә билеты бирергә кирәк.* М. Гафури. **Кәҗә бәясе** — бик арзан бәя; бик арзан нәрсә, бик буш нәрсә. [*Байгильдеев:*] *Суга алмаган зур күтәрер дигәндәй, безгә мөселман „кызыл дружиналары" төзеп маташуның бәясе — кәҗә бәясе.* К. Тинчурин. **Кәҗә калдыру** — карта, домино уенының „кәҗә" дип аталган бер төрендә оту, җиңү. **Кәҗә мае чыгу** — нинди дә булса эшне башкару өчен бик зур көч салу, бик күп көч кую, тир агызу. [*Егет:*] *Белә-сезме, нәрсә ул целина? --- Менә кайда кәҗә майларың чыга.* Ә. Еники. **Кәҗә мае(н) чыгару** — 1) бармаклар белән бик каты басып, чәчне каршыга сыпыру. *Абыйсы, сиздермәстән генә, аның кыл кебек каты кыска чәчен артка сыпырып „кәҗә маен" чыгарып алырга өлгерде.* Г. Ахунов; 2) берәр эшне башкарып чыгу өчен бик күп көч куярга мәҗбүр итү; тир түктерү. *Еллар бер урындарак торып, авылда әлеккедәй вак крестьян хуҗалыклары яшәсә, минем ише күсәкләрне сабан сөрдереп, урак урдырып, кәҗә майларын чыгарган булырлар иде.* Ф. Хөсни. **Кәҗә маңгай** *тирг.* — фикерләү сәләте югары булмаган яки акылсызрак эш иткән кешегә карата әйтелә. [*Габдулла:*] *Тик тор, кәҗә маңгай... Нәрсә әйттең, кайчан әйттең?* Һ. Такташ. **Кәҗәне кәбестә сакларга кую** — кемне дә булса ул бик ник зарар китерә алган урынга кертү, шундый җиргә керергә мөмкинлек бирү. **Кәҗә сыйрагы (аягы)** — кәгазьне озын бүрәнкә сыман итеп төреп, уртадан бөгеп тәмәке тутырып ясаган тәмәке төреме. [*Арнаутов*], *Һич тә булмаса берәр „кәҗә сыйрагы" ясарлык тәмәке алып кайтырга кирәк дигән булып, үзе дә алар ягына таба китте.* Ф. Хөсни. [*Хуҗа*] *үзг дә газетадан „кәҗә аягы" ясап, төтенли башлады.* Н. Дәүли. **Кәҗә тоягы** — кулны йодрыклаганнан соң урта бармак белән имән бармак арасыннан чыгып торган баш бармак — берәр нәрсәне бирмәү, баш тарту, мәсхәрә итү билгесе. [*Давыт*] *озын бармаклары белән кәҗә тоягы ясап, егетләрнең борын төбендә уйнатты.* А. Гыйләҗев.

КӘҖӘ II *и. диал.* 1. Борыслар, киртәләр белән аркылы-торкылы ныгытылган һәм басып эшләү өчен өстенә такталар җәелгән җайланма, терәк.

2. Пычкы белән утын кисү өчен дүрт яки алты аяклы борыс, җайланма.

КӘҖӘЛЕ *с. күч. сөйл.* Көйсез, кире. *Иң әлек ул* [*Хәбибрахман*] *үзенең кәҗәле, ләкин бик кадерле бәләкәй кызчыгы— Ләйләсе турында уйланды.* А. Расих.

КӘҖӘЛӘНДЕРҮ *ф. сөйл.* Киреләндерү; көйсезләндерү. *Дхмәтнең кытыршы сораулары да Хәмәй картны кәҗәләндермәделәр.* Х. Кәрим.

КӘҖӘЛӘНҮ *ф. сөйл.* Киреләнү; көйсезләнү. [*Бибкәй:*] *Аның башта кәҗәләнә торган гадәте бар.*

М. Фәйзи. — *Шыпырт кына сызарга кирәк. Югыйсә безнең бикә кәҗәләнә башлар.* Ш. Мөхәммәдев.

КӘҖӘЛӘҮ *ф. сөйл. к.* кәҗәләнү. — *Миһрижамалым кәҗәли башлады.* М. Гали.

КӘҖӘМӨГЕЗ *и. астр.* Көньяк ярымшардагы йолдызлык, зодиакның берсе. *Менә [йолдызлыкларның] исемнәре: --- кәҗәмөгез һәм сукояр.* Астрономия.

КӘҖӘНКӘ *и. диал. к.* кәзәнкә. [*Карчыкның*] *--- ачуы килер дә сине кәҗәнкәгә ябып куяр.* Әкият. [*Мәрьям:*] *Карак бездә нишләсен? Кәҗәнкәдәге ямаулы бишмәтеңне урласа гына.* Г. Минский.

КӘҖӘСАКАЛ *и. бот.* Оешма чәчәклеләр семьялыгыннан сөт сыман сыекча бүлеп чыгара торган үләнүсемлек; *русчасы:* козлобородник. [*Фәсхи:*] *Җиребезнең башында кәҗәсакал үсә торган* [*иде*]. Ф. Хөсни.

КӘҖҮЛ *с. иск.* Кәҗә тиресеннән эшләнгән, кәҗә күненнән тегелгән. *Кәҗүл читек.*

КӘҖҮНКӘ *и. иск. сөйл.* Революциягә кадәр: дәүләт монополиясендәге аракы сату кибете. *Хәзер юлда барганда Габдулланың исенә шул килеп төште һәм, базар башындагы кәҗүнкәгә кереп, шул „суның“ зур гына бер шешәсен алып чыкты.* Ә. Фәйзи.

КӘҖҮ'ННИ *с. иск. гади с.* 1. Дәүләтнеке булган, дәүләткә караган. *Кайткан чакта күрә юлда: кәҗүнни бүрәнәләр үрәчәсез чаналарда авылга сөйрәләләр.* С. Баттал.

2. *күч.* Формаль, рәсми. *Һәммәсе дә, борчылу күрсәтеп, кәҗүнни йомшаклык белән генә Мусаның хәлен сораштылар.* Ш. Маннур.

КӘҺВӘ *и. иск. к.* кофе.

КӘҺВӘХАНӘ *и. иск.* Кофе эчә торган урын.

КӘҺӘФ *и. иск.* Тау куышы.

КӘҢКӘЙТҮ *ф. диал.* 1. Начарландыру, йончыту.

2. Салындыру, салу. [*Песи*] *мич буенда, башын әле бер якка, әле икенче якка кәңкәйтеп, гажәпләнеп утыра иде.* Ф. Хөсни.

КӘҢКӘЮ *ф. диал.* 1. Начарлану, йончу. *Мондый шартларда эш көче кәңкәя бару рәвешендә генә саклана.* Политэкономия.

2. Салыну, бер якка авышу (мәсәлән, кикрик).

КӨБЕЛӘ *и. зоол.* Борчакны зарарлый торган кечкенә паразит бөҗәк. *„Гороховая тля“ ны халык „көбелә“ ди, кайбер урында „гөбелә“, „борчак бете“, „телә“ диләр. Минемчә, көбелә дип атау дөрестер.* М. Гаитов.

КӨБРӘ *и. бот.* 1. Көньякта җиргә җәелеп үсә торган куак сыман үсемлек; *русчасы:* каперс.

2. Шул үсемлекнең ашка тәм кертү өчен кулланыла торган бөреләре.

КӨБӘ *и. тар.* Вак металл бөжраларны бер-беренә кертеп эшләнгән борынгы сугыш киеме. *Көбә кигән Хаммат килеп чыга.* Н. Исәнбәт. *Бөтен гарәп сәүдәгәрләре кылычларын билләренә тактылар, көбәләрен өсләренә киделәр.* Г. Газиз.

Көбә кием — *к.* көбә. *Болгар осталары кулыннан чыккан көбә киемнәр, кылычлар, сөнгеләр, хәнҗәрләр, йозаклар, ялт иткән металл савыт-саба --- ул вакытның шау-гөр килеп торган күп кенә базарларында сатыла.* Каз. утл. **Көбә күлмәк** — *к.* көбә. *Корал ясау осталары --- ике ягы да үткен кылычлар һәм сугыш калканнары, ныкброня һәм көбә күлмәкләр --- ясаганнар.* СССР тарихы.

КӨБӘК *и.* 1. Винтовка, мылтык кебек ату коралларының пуляны билгеле бер ноктага юнәлтә торган көпшәсе. *Управляющийның җилкәсенә асылган ике көбәкле --- ау мылтыгы авызы белән күккә карап тора.* М. Галәү.

2. *сөйл.* Сап, тотка. *Чабагач көбәге.*

КӨДРӘ *с. сөйл.* Бөдрә, бөдрәләнеп торган, бөдрәләнеп, чорналып үскән. *Хәйдәр озын нечкә бармаклары белән көдрә чәчен араларга тотына.* Г. Бәширов. *Базарлардан бүрек алдым, каракүлнең көдрәсен.* Җыр.

КӨДРӘЙТҮ *ф. диал.* Кабарту. *Бүре ач булса да, җилкәсен көдрәйтер.* Әйтем.

КӨДРӘЛӘНДЕРҮ *ф. сөйл.* Бөдрә итү, бөдрәләндерү. *Галиев, кесәсеннән кечкенә генә көзге чыгарып, шуңар карап чәчен төзәтә, аның уртадан ачылган юлын тагы да ачыграк итәргә тырышып, ике якка сыпыра, алдагы көдрәләндергән җирен бөтергәләп куя.* Ф. Әмирхан.

КӨДРӘЛӘНҮ *ф. сөйл.* 1. *Төш. юн. к.* көдрәләү. 2. Бөдрәгә әйләнү, бөдрә булу.

КӨДРӘЛӘТҮ *ф. сөйл.* Чәчне бөдрәләтү, бөдрә итү (гадәттә парикмахердан).

КӨДРӘЛӘҮ *ф. сөйл.* Бөдрә итү, бөдрәләү (чәчне).

КӨДРӘШ: көдрәш җитен — май алу өчен игелә торган, куакланып үскән җитен.

КӨДРӘЮ *ф. диал.* Кукыраю, әтәчләнү. *Егетләр, кызлар алдына килеп, тыпыр-тыпыр биеп, бармак шартлатып көдрәеп торалар.* А. Гыйләҗев.

КӨЕ *бәйл. к.* көенчә. *Галиулла алманы агачта көе үк Маликка сатты.* И. Гази. *Вилдан --- утырган көе йоклап киткән.* Ш. Усманов.

КӨЕК *и.* 1. Нинди дә булса әйбернең яки матдәнең янганнан, көйгәннән соң барлыкка килгән калдыгы яисә көйгән урыны. *Бәрәңге көеге.* || *с. мәгъ.* Нәрсә дә булса янганда, көйгәндә барлыкка килгән. *Борынга әллә нинди авыр, күңел болгаткыч көек исе керә, күз алдында ялкын телләре уйный.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Кайгы, хәсрәт, күңелсезлек. [*Кабил:*] *дйдә --- иркен дөньяга! Кайда юк --- эч пошу, хәсрәт, көек, Кайда без иркен яшәрбез, Хөр, азат җилләр кебек.* Һ. Такташ. *Бичара, бигрәк акыллы, бигрәк зирәк, сөйкемле иде... Анасына көек булыр өчен генә туган, күрәсең.* Г. Ибраһимов.

КӨЕКЛЕ *с. иск., диал.* Кайгы-хәсрәтле, борчулы. *Көек ашаган көекле булыр.* Әйтем.

КӨЕНЕЧ *и.* Кайгы, сагыш, хәсрәт. [*Тугзак:*] *Көнче [дошман] яуга көенеч китердегез.* М. Җәлил.

◇ **Көенечкә каршы** *кер. сүз.* — нәрсәдән дә булса күңелсезләнүне, кайгыруны белдерү өчен кулланыла (*к.* кызганычка каршы). *Ләкин, көенечкә каршы, бу юлы да яңгыр яумады.* Ш. Камал.

КӨЕНЕЧЛЕ *с.* Кайгылы, хәсрәтле, борчулы. *Капкадан капкага аякланып йөрүче хәбәрләрнең сөенечлесен дә, көенечлесен дә тыңларга туры килде Гайшә карчыкка.* С. Рафиков.

КӨЕНЧЕК *и. диал. к.* көенеч. [*Мәрьям*] *шатлык белән көенчек, өмит белән шөбһә вә үкенүнең әле бер яктан, әле икенче яктан туктаусыз агымына ятып, --- эзләгәнен мәңге таба алмас шикелле бер тойгы сизә иде.* Г. Ибраһимов.

КӨЕНЧӘ *бәйл.* Үзеннән алда килгән сүз белдергән рәвештә, хәлдә. *Аны кышкы салкында яланаяк, яланбаш көенчә, штык белән чәнчи-чәнчи, урам буенча куып йөрткәннәр.* Г. Бәширов. *Туфан әсәрләре бөтен көенчә алганда мәгънә ягыннан да, художество ягыннан да эшләнгәннәр.* Г. Нигъмәти.

КӨЕНӘ *бәйл. к.* көенчә. *Сөләйман байның баласы Ибраһимның тап-таза көенә солдаттан калуы авыл халкы арасында төрле сүзләргә сәбәп булды.* М. Гафури. *Юл буенда яшь бер каен кызы Тынып йоклый баскан көенә.* Һ. Такташ.

КӨЕНҮ *ф.* Кайгыру, хәсрәтләнү, борчылу. *Зөһрә җанның бөек бәйрәмендә Эз калмасын көенеп сөйләргә.* Ф. Бурнаш. *Нәфисәнең бүтән берәүне сөюен, аның өчен шулкадәр көенүен Зиннәтнең башы сыйдыра алмый, ул кашларын җыергалап куя иде.* Г. Бәширов.

КӨЕП-ЯНЫП *рәв. сөйл.* Кайгырып, борчылып. *Берәү йөрсен көеп-янып, Берәү уйламасын да.* Җыр.

Көеп-янып бетү — 1) янып күмергә әйләнү; янып бетү; 2) *күч.* эсседән, эсселектән әлсерәү; кояшта кызу. [*Хәмидә:*] *Балакаем эссегә көеп-янып беткән.* М. Гафури.

КӨЗ *и.* Елның дүрт фасылының берсе, җәй белән кыш арасы. *Яңгырлы көз.* □ *Көз җитте исә, ындыр икмәк белән тула.* И. Гази.

Көз көне — көзен, көз булган вакытта. *Көз көне безнең әткәй шул кәсептән, йөрүдән, игеннән җыелган акчага икенче ат та алды.* Г. Ибраһимов.

КӨЗГЕ I *и.* **1.** Үзенең алдында булган предметларны чагылдырырлык итеп ялтыратылган шома өслек; кеше сурәтен һ. б. карар өчен махсус эшләнгән пыяла. *Стена көзгесе. Кесә көзгесе.* □ *Галиев, кесәсеннән кечкенә көзге чыгарып, шуңар карап чәчен төзәтә.* Ф. Әмирхан. *Пилот та Маратның кыяфәтен кабинадагы көзгедә күреп көлеп җибәрде.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Нинди дә булса күренешләрнең, процессларның чагылышы. *Белергә кирәк ки, халык җырлары— халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәүшән көзгеседер.* Г. Тукай. *Эре буржуазия органы булган „Тәрҗеман" газетасы менә шул идеологиянең көзгесе иде.* М. Җәлил. || Нәрсәне дә булса ачыкларга, белергә ярдәм итә торган чара. *Укый-яза белү—тормышыңны Ачып күрсәтүче көзге ул.* М. Гафури.

3. *күч. махс.* Нәрсәнең дә булса өслеге. *Күл көзгесенең мәйданы.*

Көзге өстәле — трюмо астындагы өстәл яки такта. *Карчык - - - көзге өстәлендәге кара печатьле озынча кәгазьгә башы белән ымлады.* Г. Гобәй.

КӨЗГЕ II *с.* Көз көне була торган, көз вакытына хас; көз көне башкарыла торган. *Көзге чәчү.* □ *Яңа бистәнең атаклы көзге пычраклары башланды.* Ә. Фәйзи. *Көзге төндә яңгыр гына Сибәли дә сибәли.* Ф. Кәрим. || Көз көне үсә яки өлгерә торган. *Менә шул көзге чәчәкләр Антанас картның, хәтта бөтен авылның тормышын астын-өскә китерүгә сәбәпче булды.* А. Шамов.

Көзге бодай — көз көне чәчелеп, шытып чыга һәм кышын кар астында кышлап, җәйдә өлгерә торган бодай. [*Тимери:*] *Без монда быел көзге бодай чәчәбез.* Г. Бәширов. **Көзге пальто** — көз һәм яз көне кия торган пальто. *Газета сатучы кечкенә Карл Гәрәйнең көзге пальтосы эчендәге кызыл галстугына бармагы белән төртте.* А. Алиш. **Көзге чебеш** — көз көне басып чыгарылган, үсеп, ныгып өлгермәгән чебеш. *Көзге чебеш кебек бичаралар, Мич башына куйсаң — туңалар.* һ. Такташ. **Көзге этәч** — 1) яшь этәч. *Д үзләре, көзге этәч шикелле, бер-берсенә капма-каршы килеп басканнар.* А. Әхмәт; 2) *күч.* бәйләнчек һәм сугышучан яшүсмер турында. **Көзге өлешкә** — көз көне ашау өчен, көз өчен билгеләнгән. *Тары, карабодай кебек көзге өлешкә дип чәчелгән ашлыкны сугып, келәтнең өскәрен тутырасың.* Г. Ибраһимов.

КӨЗГЕЛЕ *с.* Көзгеләп эшләнгән. *Көзгеле күзлек. Көзгеле шифоньер.*

Көзгеле гальванометр *физ.* — кәтүге көмештән яки фосфорлы бронзадан ясалган нечкә металл чыбыкка асып куелган гальванометр.

КӨЗГЕЛЕК *с. сөйл. к.* көзлек. *Көзгелек ашлык.*

Көзгелеккә калдыру *диал.* — *к.* көзлеккә калдыру.

КӨЗГЕЛЕКТӘ *рәв. сөйл.* Көзен, көз җиткәч. [*Әпипә:*] *Көзгелектә каз бәлешенә дәшәрсеңме?* Г. Бәширов.

КӨЗГЕЛӘНҮ *ф. сөйл.* Көзге кебек ялтырау, көзге кебек шомага әйләнү. *Нургали киң урам уртасыннан, көзгеләнеп катkан һәм тоныk кына елтырап яткан чана юлы буйлап - - - китте.* Ә. Еники.

КӨЗГЕЧЕ *и.* Көзге ясаучы оста, көзге коючы.

КӨЗГӘ *рәв.* Көзен, көз җиткәч. [*Гайшә:*] *Аның каравы көзгә үзеңне чебеш канаты белән генә сыйлармын.* Ф. Бурнаш. — *Кырыкмышыңны каравылга куярга риза буласыңмы? Җәмгать җыенында халык җәй буена акчалата егерме сум, биш арба ботак утыны, көзгә ун пот арыш бирергә булды.* М. Гали.

КӨЗГӘ'ЧӘ *рәв.* Көзгә кадәр, көзгә хәтле; көз башланганчы. *Көзгәчә көтү.*

КӨЗДӘ *рәв.* Көзен, көз көне. *Язда булса гөрләвекләр, Көздә ява яңгырлар.* М. Җәлил. *Инде баеп җитәм дигәндә, каты бураннлы, яман бозлы бер көздә аның күп хайванын җот һәлак кылды.* Г. Ибраһимов.

КӨЗДӘН *рәв.* Көзен, көз вакытында. *Язга көздән көч хәзерләп, Үсә безнең ил.* Ф. Кәрим. *Ул корткычлар [әрләннәр] азыкны көздән бөтен кышка җитәрлек әзерләп куялар икән.* Г. Гобәй.

КӨЗЕН *рәв.* Көз вакытында, көз көне. *Көзен Идел туңганнан соң, - - - [Тимери] лашман ягына китте, урман кисеп, сал бәйләргә ялланды.* Г. Бәширов.

КӨЗЛЕК *с.* Көз куллану өчен билгеләнгән. *Көзлек бәрәңге.*

◊ **Көзлеккә калдыру** — көз куллану, файдалану өчен калдыру.

КӨЗЛИ *рәв. сөйл. к.* көзен. [*Галиулла:*] *Исән булсак, сыерны табып алып булыр. Менә алмалар уңса, - - - көзли үк.* И. Гази.

КӨЗЛӘҮ *ф. сөйл.* Көзне үткәрү; көз буе яту.

КӨЗСЕЗ *рәв.* Көз булмыйча, көз кермичә; көз җитмичә. [*Җәүһәрия:*] *Мин барыбер көзсез китмим. Д хәзер әле бары яз башы гына.* Р. Ишморат.

КӨЗӘН I *и.* Сусарлар семьялыгыннан кыйммәтле мех бирә торган зур булмаган җәнлек. *Ак көзән. Кара көзән.* □ *Иртәгесен Гата, чыгып капкынын караса, шакката: авызын ачкан көзән ята.* А. Алиш.

КӨЗӘН II: **көзән җыеру (тарту)** — үзеннән-үзе мускуллар кыскару, мускуллар тартышу (авыртудан, суыктан һ. б.). [*Гайнетдин:*] *Хәзер көзән җыера башлый ахры.* Ш. Камал. — *Менә шунда бервакыт, аякларымны көзән җыерып, мин бата башладым.* Ә. Айдар.

КӨЙ I *и.* **1.** Авазларның (тоннарның) билгеле бер тәртиптәге эзлеклелегеннән гыйбарәт музыкаль бербөтен. *Җырлау өчен язылган әсәрләрдә көйнең роле бик зур.* М. Фәйзи. *Шагыйрь күңелендә яңа җырның, композитор күңелендә яңа көйнең иң беренче тапкыр ничек туа башлавын Газинур Белми иде.* Г. Әпсәләмов. || Нинди дә булса бер музыкаль әсәр. *Шәмсетдин, аягын бөкләп сәке түренә менеп утыра да, ниндидер бик борынгы бер көйгә сузып-сузып скрипка сыздырырга тотына.* Г. Бәширов. *Габденнасыйр кыштәдән үрелеп курай алды да озын көйгә уйнарга кереште.* М. Гали. || Җырлау өчен сүз һәм музыкадан гыйбарәт әсәр. *„Әтнә" көенә җырласам, Ашкына йөрәкләрем.* Ә. Ерикәй. *Булат „Шахта" көенә җырлап керә.* К. Тинчурин.

2. Нәрсә дә булса чыгарган аһәңле тавыш. *Җил тегермәннәре, авылның салам башлы, кечкенә тәрәзәле өйләре, гүя ки, һәммәсе дә „э-э-э" дип озайтып, шул эчпошыргыч көйне сузалар.* Ш. Камал.

Көе килү — мелодиясе туры килү, музыкасы туры килү. *Хәтта такмак та чыгарып булмый. Сүзе килсә — көе килми, көе килсә — сүзе килми.* А. Шамов. **Көйгә салу** — җырлау, башкару өчен ярарлык хәлгә китерү. **Көй көйләү** — 1) җырлау, җыр җырлау (сүзләр белән яки сүзсез), музыкаль әсәр башкару; 2) авазлар чыгару, тавыш барлыкка китерү. *Исә җил, авыр кайгылы; куркыныч көйләрне көйли ул.* һ. Так-

таш. **Көй чыгаручы** *сөйл.* — композитор, музыка язучы. *Үз улың көй чыгаручы, кызлар бармак очларына гына басып бии торган балетлар язучы була торып, театрдан театрга гына йөрмәгәч аны.* Ш. Хөсәенов.

◇**Көен җырлау** — кемнең дә булса карашын, эшен яклау; берәр эштә кемнең дә булса карашын үткәрү (*к.* җырын җырлау). *Ул найманнар көен җырлаучы адәм иде.* Г. Ибраһимов.

КӨЙ II *и.* Нинди дә булса бер җай, бер уңай, бер тәртип. *Аның көенә туктап-туктап барды, ул утырып ял иткәндә көтеп алды.* Г. Гобәй. *Тормышыбызны бер көйгә җайлап җибәрсәк тә, без яңаданяңа теләкләр һәм бурычлар белән янып яшибез.* Ә. Еники.

◇**Көе килү** — уңае туры килү, кәефе килү, кәеф булу. *Мәрфуга килен - - - көе килгәндә бик әйбәтләп булышкалый.* Г. Ибраһимов. **Көе китү** — бозылу, эше бозылу, эшнең рәте чуалу. *Бригаданың күзгә күренеп көе китте.* Г. Ахунов. **Көен көйләү** — кәефен китерү, күңелен табу. *Җитмәсә, син аның көен көйләп йөр, - - - аңар тегене ясап бир, моны ясап бир.* Г. Гобәй. **Көен күрү** — *к.* күңелне күрү. [*Хөрмәтулла:*] *Аннан инде яңадан фронтка барырга исәбем юк: өяздәге түрәләрнең көен күргәч кирәк.* Т. Гыйззәт. **Көенә тору** — кемнең дә булса теләгенә каршы килмәү, ул дигәнчә эшләү. **Көйгә килү** — 1) билгеле бер эш башкарырлык хәлгә килү, җайлану (эш кораллары һ. б. турында). [*Агач сабан*] *нишләтсәң дә көйгә килми.* М. Гафури; 2) уңайлану, яхшыга әйләнү (кешенең үз-үзен тотышы, тәртибе турында). [*Бибкәй:*] *Аның башта кәҗәләнә торган гадәте бар. Соңыннан көйгә килә ул.* М. Фәйзи. **Көйгә китерү (бастыру)** — берәр эшне башкарырга ризалату, күндерү; яхшыга әйләндерү.

КӨЙГӘ *бәйл. к.* көенчә. *Бүлмәнең ачкычы ишекнең тышкы ягына эленгән көйгә кала.* Г. Ибраһимов. *Мин бик ялкауланып кына, җиргә йөзтүбән яткан көйгә, баш очымдагы кечкенә-кечкенә каты балчык кисәкләрен алам.* М. Гали.

КӨЙГӘЛӘК *с. сөйл.* Тиз борчылучан, тиз кайгыручан. [*Ядвига:*] *Алай көйгәләк булма, Наилә. Диңгездә балык үлми.* Б. Камалов.

КӨЙДЕРГЕЧ *с.* 1. Яндырып, көйдереп ала торган. — *Башкаланы дәһшәтле сугыш күкрәве дереддәтми, канонадалар тынган, сугыш җәһәннәменең көйдергеч ялкыны башкала күгендәге соры болытларда чагылмый иде.* Г. Гобәй.

2. *күч. кит.* Бик көчле, ачы (хис турында). *Шушындый минутларда яңа туган балаларның бишекләренә бомбалар ташларга хәзерләнүче фашистларга, сугыш уты кабызучыларга нинди көйдергеч нәфрәт кабынмый да, нинди ярсу тумый.* Г. Әпсәләмов.

КӨЙДЕРҮ *ф.* 1. Нинди дә булса предметның тышкы ягын, чит-читләрен каралганчы яндыру, күмерләндерү. *Пуля тишеп чыккан карточкаңны, Кырыйларын ялкын көйдергән.* Ә. Ерикәй. *Бөтен тирә-як, утлы өермә көйдереп узгандай, кара янган.* Г. Бәширов. *Камырын күмердә көйдереп ашагач, Хәлим бер читкә китеп утырды.* И. Гази. || Киптерү, корыту. *Эссе һава бөтен дөньяны көйдерә.* □ *Җәйге эссе кояш тау итәкләрендәге үләннәрне көйдергәч, гаять күп терлек көтүләрен тауларга куып алып китәләр.* Физ. геогр.

2. Кыздыру, эсселәтү (кояш нурлары, эссе һава турында). *Көньякның кояшы, тәннәрне Көйдереп, миләрне кайната.* Ә. Исхак.

3. *күч.* Кайгы уяту, хәсрәтләндерү; борчу. *Шуннан соң инде бер төрле күңелсез хәбәр дә аны әлекке кебек яндырмады, көйдермәде.* Г. Ибраһимов. *Ах, бу дөнья хәйләкәр соң — Зур сарайлар салдыра, Бәгъреңә ут тамдыра да Көйдерә һәм яндыра.* Ф. Бурнаш.

4. *күч.* Бик каты тәнкыйть итү. *Т. Гыйззәт - - - үзенең төп игътибарын ул замандагы хәзрәтләрне, абыстайларны, байларны, казый һәм хәлфәләрне фаш итүгә, мәдрәсәдәге һәм хәзрәт семьясындагы җирәнгеч якларны сатира уты аша көйдерүгә юнәлдергән.* М. Җәлил.

КӨЙЛЕ I *с.* 1. Аһәңле, музыкаль яңгырашлы. *Аның йомшак, көйле тавышында, матур итеп кеткелдәп көлүендә, яхшылык аңкытып торган мөлаем күзләрендә һәм бөтен торышында ниндидер, җанны тынычландыргыч бер көч бар иде.* А. Шамов. *Озак та үтмәде, соры караңгылык эченнән көйле тавышның иясе үзе дә калкып чыкты.* Г. Бәширов.

2. Көйләп укыла торган, билгеле бер көйгә салып укыла торган. *Кич белән кайчак укыйлар, тыңлыйсың төрле китап, Кайсысы көйсез була һәм кайсысы көйле китап.* Г. Тукай. [*Г. Камалның*] *„Азатлык“ исемендәге шигыре революциягә кадәр атаклы булган „Алма китабы“ исемле бер кечкенә көйле китапка ияреп язылган.* М. Гали.

КӨЙЛЕ II *с.* Җайлы, уңайлы; тәртипле, тәртипкә салынган. — *Маратның эшләре көйле монда!* Г. Гобәй.

КӨЙЛЕЛЕК *и.* 1. Көйле (I) булу. *Җырның көйлелеге.*

2. Көйләп укыла торган булу. *Барыннан да элек, классик поэзия нигезендә яткан көйлелекнең акрынлап булса да декламация интонациясе белән арала-шуы - - - сизелде.* Г. Халит.

КӨЙЛӘГЕЧ *и. махс. к.* регулятор.

КӨЙЛӘМ *с. махс.* Көйләп укуга нигезләнгән, көйләп укыла торган. *Такташ көйләм шигыреннән сөйләм шигыренә күчү, шигырьдә табигыйлек мәсьәләләрен куйган иде.* Х. Госман.

КӨЙЛӘНҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* көйләү II. *Бер читтәрәк—су эчәр өчен махсус көйләнгән, югарыга су ургып тора торган кран.* Р. Ишморат.

2. Тәртипкә салыну, эзгә төшү, җайлану (тормыш, эш. һ. б. турында). *Уракка төшәр алдыннан Тимергә эшнең һәммә ягы да көйләнгән кебек иде.* Г. Бәширов. *Колхозның эшләре көйләнә башлаганлыгын ишеткәч, - - - Сафа - - - тәрәзәләре кадакланып куелган өенә яңадан кайтып керде.* А. Расих. || Тормышны, эшләрне эзгә салу, уңайлы итү. *Ни диярсең син, әгәр дә мин өйләнсәм, Кеше төсле урынлашсам, көйләнсәм.* Г. Тукай.

3. *сөйл.* Әзерләнү, җыену. [*Отто:*] *Бар, иптәш, юлга көйлән, алырмын сине үзем белән.* А. Алиш. || Җайлашу, күнегү. *Кыш суыкларына буйсыну, көйләнү чоры башланды.* Сов. әд.

КӨЙЛӘП-ЧӨЙЛӘП *рәв.* Сүзләр белән юатып. [*Сәфәр:*] *Безне, көйләп-чөйләп тынычландырып, кайтарып җибәрделәр.* Ә. Фәйзи.

КӨЙЛӘҮ I *ф.* 1. Нинди дә булса бер көйне башкару, бер көйгә җырлау. [*Шәйхел*] *кымыз мәҗлесләрендә, көр тавыш белән, башкортның нәкъ үзе булып, „Ашказар“, „Сакмар“, „Шүрәкәй“ җырларын көйләде.* Г. Ибраһимов. || Музыкаль авазлар чыгарып, сүзсез нинди дә булса бер көй сузу. *„Зәңгәр күзләр“ көен көйли-көйли, Сулар агызам тирән күлләрдән.* Һ. Такташ. *Рәхим, алып кайткан әйберләрен шкафка алып куя-куя, авыз эченнән көйли.* Р. Ишморат. || Ба-

лаңы тирбәтеп йоклатканда җырлау. *Иң әлек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән.* Г. Тукай.

2. Нинди дә булса авазлар чыгару, көйле тавышлар чыгару (җансыз әйберләр турында). *Көйләп утырган самовар тавышына Бәдри белән Җәмиләнең тавышлары кушылып, бик хәсрәтле генә тормышны искә төшерә.* М. Гафури.

3. *иск.* (Шигырьләрдә) сөйләү, сурәтләү. [*Такташ*] *авыл турында, аның хезмәт ияләре әченнән диварында Ленин рәсемен асраучы советчы Шәхми карт-лары үсеп чыгуын көйләде.* Г. Нигъмәти.

4. *рәв. мәгъ.* **көйләп.** Нинди дә булса көйле тавыш чыгарып, көйле тавыш белән. *Мин аларны күңелемнән яхшы ятлап, көйләп укып йөрсәм дә, язга кадәр ике хәрефне бергә кушып әйтерлек һәм аерым-аерым рәвештә аларны китаптан күрсәтә алырлык хәлгә килмәдем.* М. Гали.

5. *рәв. мәгъ.* **көйләп.** Көйгә салып, көйләп укылырлык итеп. [*Китап*] *үзе бер генә табак чамасы булып, көйләп язылган иде.* М. Гафури.

Көйләп әйтү — көйле тавыш белән әйтү, сузып әйтү. [*Хатын:*] *Дә, мескеннәремне ничек кызганмаганнар! — дип, көйләп әйтеп куйды.* А. Шамов.

КӨЙЛӘҮ II *ф.* 1. Кору, җайлау; эшкә җайлау (машинаны, аппаратны һ. б.). — *Сложный молотилканы көйләгәнсең икән, шуңа бик сөендем әле, рәхмәт, энем.* Р. Ишморат. — *Фермада салам кискеч машинаны да электрга көйләп җибәрдек.* Ә. Еники.

2. Рәтләү, рәткә салу, җайлау, тәртипкә китерү (эшне һ. б.). [*Солтан:*] *Ферма эшен көйләү өчен нилләр җитми?* А. Расих. || Оештыру, җайга салу, башлап җибәрү. — *Үзара ярыш дигәнен дә көйләп җибәрәсе булыр, агитаторга әйтермен.* Г. Бәширов.

3. Әзерләү, җәю (мәсәлән, урын-җирне). *Урын көйләп биру.*

4. Күңелен табу. *Кунак булып йөрмәгән кунак көйли белмәс.* Мәкаль. *Үзе көн-төн эшләгәч, аңа эшсез яткан хатынын назлау да, көйләү дә торган саен авырга килә башлады.* Ә. Еники. || Юмалау, юату. *Апалар аны ничек кирәк алай көйләп, бәхилләтеп җибәрделәр.* А. Шамов.

КӨЙМӘ I *и.* 1. Суда йөзү өчен зур булмаган судно. *Моторлы көймә. Җилкәнле көймә. Дүрт ишкәкле көймә.* □ *Көймәнең ныклыгы давыл чыккач беленә.* Мәкаль. [*Илсөяр*] *шактый түбән аккан көймәсен агымга каршы борып, үз якларына таба каерып-каерып ишә башлады.* Г. Гобәй. || *иск.* Пароход. *Югарыдан килә торган бик озын трубалы, ике якта бик зур тәгәрмәчле зур кара көймә күренде. Аның трубасыннан очкын белән катыш кара төтен чыгып бара иде.* М. Гали. || Кайбер хәрби суднолар-ның тезмә исемнәре составында кулланыла. *Каноңер көймә.* □ *Улың синең су астында, Су асты көймәсендә.* М. Җәлил.

2. Рессорларга утыртылган, дүрт тәгәрмәчле, бөтен яктан да ябык арба; экипаж. *Аңа күз яше арасыннан караңгы төннәр, зур кара көймәгә җигелгән зур кара атлар, Сабирның, шул көймәгә курыкмыйча утырып, әллә нинди караңгы, билгесез дөньяга кереп китеп югалулары берәм-берәм күз алдына килә.* Г. Ибраһимов.

3. Өстәмә рәвештә кеше утырту яки йөк йөртү өчен мотоциклга беркетелгән тәгәрмәчле җайланма, кечкенә арбачык. *Көймәсез мотоцикл, мотороллер һәм мопед йөртү стажы бер елдан ким булган кешеләргә пассажирлар утыртыу тыела.* Соц. Тат.

◊ **Көймә комга терәлү** — авыр хәлдә калу; эш бик ныкавырлашу. *Сөйләргә дисәң — булдырам, әмма яза башласам — көймәм комга терәлә.* Г. Әпсәләмов.

Көймә II *и.* Нинди дә булса корылманың (мәсәлән, мичнең) эчке стеналарын өске яктан уратып тоташтыручы түшәмә. *Миңнур картның мичe бозылды: башта ул бик каты төтенләп газаплады, аннары аның көймәсе дөбердәп ишелеп төште.* А. Шамов. [*Миша:*] *Тиз коюга ирешү өчен ничә мич көймәсен эреттегез?* Н. Исәнбәт.

КӨЙМӘЛЕ: көймәле арба — рессорларга утыртылган, дүрт тәгәрмәчле, бөтен яктан да ябык арба, экипаж (*к.* көймә 2). — *Апамны көймәле арбага кутәреп утыртулары, озатырга килгән хатын-кызларның күплеге --- бик нык истә калган.* М. Гафури. **Көймәле чана** — бөтен яктан да ябык чана.

КӨЙМӘЛӘП *рәв.* Көймә (II) формасын бирепе, түбәсен көймә рәвешенә китереп. *Бу вокзал, чиксез зур итеп, көймәләп эшләнеп, башын пыяла белән япкан лабазга охшый.* Г. Гали.

КӨЙМӘЧЕ *и.* Кешеләрне көймә белән елга, күл аша чыгаручы; шул эш белән кәсеп итүче. *Көймәче бу кешеләрне суның арьягына күчергәч тә, куллары белән күрсәтеп, юллар тәгъриф итә* [*аңлата*] *иде.* Ш. Камал. *Кая киткән карт көймәче, Ник яшереп киткән ишкәген?* Ф. Кәрим.

КӨЙРӘК *с. сөйл.* Борчылучан, тынгысыз. *Көйрәк үзен бетерер, сабыр эшен бетерер.* Мәкаль. *Ни дисәң дә, туган яклар шул. Шуңа башын бөгеп утыра инде бу көйрәк җан.* Г. Ахунов.

КӨЙРӘКЛӘНҮ *ф. диал.* Борчылу, артык кайгыру. [*Гәрәй*] *артыгын кызмады да, көйрәкләнмәде дә.* А. Гыйләҗев.

КӨЙРӘТҮ *ф.* 1. Мич, учак кебек урыннарда утны яндыру, яндырып җибәрү. *Ирен көтеп, ашын унынчы кат Җылытыр өчен учак көйрәтә.* М. Җәлил.

2. Утлы күмердән, янып торган тәмәкедән, папиростан яки шырпы белән кабызу. *Гәлекәй Габдулла өчен төреп бирде, Талип көйрәтер өчен аңа үз тәмәкесен сузды.* Ә. Фәйзи. *Улҗабай, торып утырып, папиросны алды. Көйрәтте. Озак итеп суырды.* Каз. утл. || Тарту (тәмәке, папирос һ. б. ш.). *Алар байтак вакыт һәр икесе, үз уйларына чумып, тын гына утыралар һәм тәмәке көйрәтәләр иде.* Г. Әпсәләмов. [*Габтелмән:*] *Күләгәгә утырып, көйрәтеп алыйм әле бер.* Р. Ишморат.

КӨЙРӘҮ *ф.* 1. Чит-читләре яки тулысынча күмергә әйләнеп яну, кузга әйләнеп яну. *Утлы күмер өстендә көйрәп яткан хатның зәңгәр ялкынына текәлеп, Нәфисә озак уйланды.* Г. Бәширов. *Бераздан* [*өй*] *тоташ күмергә әйләнде. Кып-кызыл булып, байтак вакыт көйрәп торды.* А. Расих.

2. Кызудан, эсселектән кибеп кору (үләннәр, үсемлекләр һ. б.). *Инеш буендагы талларга хәтле яфракларын коеп, сусызлыктан көйрәп утыралар.* К. Нәҗми.

3. *күч. сөйл.* Сусау, бик нык эчәсе килү. *Туктa әле, нәрсә ашап ул кадәр көйрәдең? — дип, Фатыйма гөжләп утырган самовар янына китте.* И. Гази.

4. *күч.* Нинди дә булса хис белән яну турында. *Шулай бара ике йөрәк, Ялкын эчендә көйрәп.* М. Җәлил.

КӨЙСЕЗ I *с.* Аһәңсез, начар көйле (җыр, музыка турында). *Көйсез җыр.* □ *Егет булып килә торган бер малай, гармоньга кушылып, тамак төбе белән шырыйлап кычкыра, көйсез итеп җырлый.* Г. Бәширов. || Көйгә салынмаган; шигъри калыпта булмаган. *Кич белән кайчак укыйлар, тыңлыйсың төрле китап, Кайсысы көйсез була һәм кайсысы көйле китап.*

Г. Тукай. | *рәв. мәгъ. Һәркемдә язуга һәвәс артып китте, кайсы көйләп, кайсы көйсез генә язарга тотындылар.* Г. Камал.

КӨЙСЕЗ II *с* 1. Җайланмаган, эшкә яраклы хәлгә китерелмәгән. *Сабанның көйсез булуы --- эшне чиксез авырлатты.* М. Гафури.

2. *сөйл.* Начар, канәгатьләнерлек түгел (эш һ. б. ш. турында). [*Комиссиянең җитәкчесе:*] *Көйсез икән сезнең эшләр, зерә дә көйсез икән.* Г. Бәширов. || Кимчелекле, уңайсыз, начар. *Тарының көйсез яклары да бар бит: ул соң өлгерә.* Г. Гобәй.

3. *сөйл.* Тәртип булмаган, тәртипкә салынмаган, җайсыз, тәртипсез. *Өй эче әллә нинди ямьсез, көйсез --- иде.* Ш. Камал.

4. *күч.* Начар холыклы, үҗәт; капризлы. *Сары бия, көйсез хатыннар кебек, чыелдап, тибенеп дулый башлады.* Г. Ибраһимов.

5. *рәв. мәгъ.* Күнелсез, кәефсез. *Көйсез күренү.*

КӨЙСЕЗЛЕК I *и.* Көе булмау, көе начар булу (җырның, музыканың). *Җырның көйсезлеге.* || Көйләнмәгән булу, көйләнмәгәнлек; көе киткән булу (музыкаль инструментларның).

КӨЙСЕЗЛЕК II *и.* 1. Җайланмаган булу, көйсез булу. *Сабанның көйсезлеге.*

2. *сөйл.* Начар булу. *Эшнең көйсезлеге.*

3. *күч.* Начар холыклылык, үҗәтлек, үзсүзлелек. *Бу [әнкәй] тарафыннан гади бер көйсезлек кенә түгел иде.* Ш. Камал.

КӨЙСЕЗЛӘНҮ I *ф.* Көе китү, аһәнлеге бозылу (музыкаль инструментлар турында).

КӨЙСЕЗЛӘНҮ II *ф. сөйл.* 1. Җае китү, бозылу; чуалу (эш һ. б. турында).

2. *күч.* Холыксызлану, каприслану, нигезсез теләк белдерү. [*Малай*] *көйсезләнсә, алдына күз камаштыргыч яңа алтын тәңкәләр чәчеп аны юаттылар.* Ә. Фәйзи. || Нервлану, борчылу; холыксызлану. *Акчаны бүлешкәнче, хәтта бүген иртәдән башлап көйсезләнә башладылар.* Ш. Камал.

КӨЙСЕЗЛӘҮ *ф.* Җаен җибәрү, бозу (мәсәлән, эшнең). || *диал.* Борчу, комачаулау.

КӨЙШӘНҮ *ф. диал.* Кыймылдау, сизелер-сизелмәс хәрәкәтләнү.

КӨЙШӘҮ *ф. диал. к.* күшәү. *Яңа туган бер бозау көйшәп ята иде.* М. Галәү. *Бер кырыйдарак киртәгә бәйләгән зур гына алпавыт аты печән көйшәп тора.* Г. Бәширов.

КӨЛ *и.* Нинди дә булса матдәне яндырганнан соң барлыкка килгән, янмый торган, аксыл соры төстәге тузан сыман минераль калдык. *Алар икенче көнне, өй буенча кереп йөреп, көл җыйдылар.* Г. Гобәй. *Нургали тәмәкесенә җыелган бармак башы кадәр көлне кагып төшерде.* Ә. Еники. || Утлы көл, көл катнаш утлы күмер. *Абый белән без капчыкларыбыздан бәрәңге чыгарабыз да, аны көлгә күмеп, утны болгата-болгата бәрәңге пешкәнен саклап ятабыз.* М. Гали.

Көл савыты—*к.* көллек 1.—*Көл савытларын, тимер каплы шырпыларыгызны үзегез яратмаган, дошманрак күргән кешеләрегезгә өләшеп, бүләк итеп бетерегез.* Г. Мөхәммәтшин. **Көл төсле (төсендәге)**—аксыл соры, соргылт. [*Кәккүк*] *күгәрченнән зуррак, кечкенә башлы, җилпәзә койрыклы, көл төсендәрәк бер кош икән.* Ә. Еники. [*Бикбулатның*] *салам юанлыгы гына итеп калдырылган көл төсле мыегы мыскыллап кыйшайды.* Г. Бәширов.

◊ **Көл булу** — янып юкка чыгу, янып бетү. *Каралтылар, йортлар, баганалар Ут эчендә калып көл булган.* Ә. Ерикәй. **Көл булып күккә очу** — *к.* көле күккә очу. *Низам бай йорты-җире белән көл булып күккә очар — анда да Сәрби Галимҗанга булмас.* Ф. Бурнаш. **Көл итү, көлгә әйләндерү** — юк итү, бетерү, юкка чыгару. *Тау-ташларны көлгә әйләндерә Торган снарядлар, зур туплар.* М. Гафури. *Берләшик сафларга Ватанны сакларга, Котырган дошманны Көл итеп ташларга.* Ә. Исхак. **Көлгә очу** — юкка әрәм булу, юкка чыгу. *Гомер буе сөргән җиргә борылып карыйм: Көлгә очкан файдасыз көч.* М. Җәлил. **Көлгә әйләнү** — *к.* көл булу. — *Дөрләп янган мәхәббәт яна да бетә, көлгә әйләнә, ә җылыта торган мәхәббәт озын гомерле була.* Р. Ишморат. *Бервакытта пыр тузарсың, әйләнерсең көлгә син!* М. Гафури. **Көлдән төймә төю** — теләсә нинди эшне булдыру, теләсә нинди эш кулдан килү. — *Минем улымның куллары әнә шундый эшкә бик сәләтле. Болай булса, үсә төшкәч, көлдән төймә дә төяр.* З. Бәшири. **Көле күккә очу** — юкка чыгу, бетү; җимерелү. *Таллык артыннан шаулаша-шаулаша бер төркем кызлар килеп чыкты, һәм шунда ук тал күләгәсендәге тынлыкның, салмаклыкның көле күккә очты.* М. Әмир. **Көлен күккә очыру** — 1) юк итү, бетерү. [*Әгъләм:*] *Алпавыт-заводчикларның көлләрен кем күккә очырды? Без — эшче һәм крәстиәннәр!* С. Рафиков; 2) бик нык тәнкыйтьләү; бик каты сүгү. [*Галим мулла:*] *Тагы тыңламасалар, көлләрен күккә очырыр идем мин ул этләрнең.* Г. Ибраһимов.

КӨЛДЕРГЕЧ *с.* Көлдерә торган, көлкеле, мәзәкле. *Әби төрлечә кыланып, көлдергеч хәрәкәтләр ясап биш.* М. Фәйзи.

КӨЛДЕРГЕЧЛЕК *и.* Көлдергеч булу, көлдерә торган булу. [*Шигырьдә*] *уйландырырлык тирәнлек тә юк, көлдергечлек ягы да цирк клоуннарыныкына караганда бик түбән, бик тупас һәм чәйнәлгән әйберләрдән гыйбарәт иде.* Ш. Камал.

КӨЛДЕРДӘҮ *ф. диал. к.* келтерәү. *Әбием иренми, Көнозын җеп эрли, Орчыгы көн бии, Төн бии, көлдерди.* Н. Исәнбәт.

КӨЛДЕРҮ *ф.* Көлү китереп чыгару; көләргә мәҗбүр итү. *Почмакта отряд агитаторы Гайфи, ике туташ арасына утырып, аларга әллә нәрсә сөйләп әчләрен катырганчы көлдерә.* Ш. Усманов.

КӨЛЕМСЕРӘҮ *ф.* Беркадәр елмаю, елмая төшү. *Алар миңа, җиңел көлемсерәп, Борыла-борыла карап үттеләр.* Ш. Маннур. || Беркадәр елмаеп үзеннең тойгыңны, хисеңне белдерү. *Хәят акрын гына әминәнең ботына төртте дә, мәгънәле генә көлемсерәп, аның күзләренә карады.* Ф. Әмирхан. *Әмиржан ачы итеп көлемсерәде.* Ш. Камал.

КӨЛЕМСӘ *с.* Көлемсерәп әйтелгән, көлүне белдергән; куанычны чагылдырган. *Шунда арттан кемнеңдер көлемсә шаян тавышы ишетелде.* Г. Әпсәләмов.

КӨЛЕМСӘР *с. сөйл. к.* көлемсә. *Шатлык һәркемнең көлемсәр карашында, оча-куна йөгүләрендә сизелә.* С. Сабиров.

КӨЛЕНЕЧ *с. диал.* Көлкеле, көлкеле булган. *Бер басуга карыйм, бер—үземә, --- Ачы көленеч хәлем күренә.* Ш. Маннур. || *рәв. мәгъ.* Көлке, көлке булып. *Көленеч тоелу.*

КӨЛЕНЕЧЛЕ *с. диал.* Көлкеле, көлдерә торган. *Чеховның көлкесе—һәр күңелле кәефне белдергән фәкать көленечле нәрсәләрне генә күрсәтүдән гыйбарәт көлке.* Г. Нигъмәти.

КӨЛЕШ *и.* Бергәләшеп көлү, күмәкләп яңгыратып көлү. *Өйдә, йортта шау-шу, көлеш, Җырга күңел нечкәрә.* М. Җәлил. *Шау-шу, көлеш эчендә шәкертләр бу спектакльнең уңышлы чыгуыннан кинәнделәр.* Ә. Фәйзи. || Көлү рәвеше. *Гөлҗамал әби, аның бу матур итеп көлешенә нишләргә дә белмичә, --- [баланы] кулына алды.* М. Гали.

КӨЛЕШҮ *ф.* Күмәкләп көлү, бергәләшеп көлү. *Малайлар, әле генә бәрелешергә торганнарын онытып, көлештеләр.* Г. Гобәй.

КӨЛКЕ *и.* 1. Көлдерә торган, кызык күренеш, кызыклы вакыйга, хәл. *Минем елавым шәкертләр өчен көлке генә булды.* М. Гафури. [*Ул*] *кунакларның һәммәсенә, әчендәге салкынлыгын яшерергә тырышкан бер кыяфәт белән, берәм-берәм көлкеләр сөйләде, бераз шаярды.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Көлдерә торган. *Ул, ниндидер көлке әйбер турында сөйләп, яшьләрнең игътибарын үзенә тартырга маташа иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Көлү, көлешү. *Бу юлы башкалар да көлгәнгә генә, карт үзе дә көлкегә кушылып, аптыраган кыяфәттәрәк бераз көлемсерәп торды.* Ш. Камал.

3. *иск. кит.* Кечкенә күләмле юмористик яки сатирик әсәр; комедия. *Икенче пьеса „Хат болгатты!" исемендә бер пәрдәлек көлкедер.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ. иск. кит.* Сатирик, юмористик (әсәр, журнал); сатирик (образ). *Казанда беренче көлке журналы „Яшен" чыга башлады.* М. Гали. *Андагы хажи, Кисекбаш, шәкерт, дию һәм Карәхмәт — барысы да көлке типлар.* М. Җәлил.

◇**Көлкегә калдыру** — көлү объектына әйләндерү, уңайсыз хәлгә калдыру. *Гаяз үзе дә мине көлкегә калдырырга тырышмый иде.* М. Әмир. **Көлкегә калу** — кешеләрнең мыскыллап көлүләренә дучар булу, мәсхәрәгә калу. [*Тимерхан:*] *Районда гына түгел, бөтен республика күләмендә көлкегә калырбыз.* Т. Гыйззәт. **Көлкегә күтәрү** — *к.* көлкегә калдыру. *Эшчеләр, көлкегә күтәреп, хур иттеләр үзләрен.* Һ. Такташ. **Көлкегә җибәрү** — көлкегә әйләндерү. *Әкбәр* [*сүзне*] *- - - көлкегә җибәрә башлаган иде, укытучы бүлдерде.* Г. Гобәй.

КӨЛКЕЛЕ *с.* Көлдерә торган, көлке уята торган; мәзәк булган. — *Хөснетдин Саматов көлкеле кыска хикәя сөйләде.* Ш. Камал. *Бу типларны шулкадәр көлкеле кыяфәттә бирү өчен, шул тормышны бик нык белү өстенә, күрә алмаслык дәрәҗәдә аңа дошманлык хисе булуы кирәк.* М. Гали. | *рәв. мәгъ. Хәзер башына марлядан чалма чорнаган Салих шулкадәр көлкеле күренә иде.* Ш. Усманов.

КӨЛКЕНЕЧ *с. сир. к.* көлкеле. *Минемчә, Карәхмәтне бөтенләй башкача, Тукайча эшләргә кирәк. Ул көлкенеч тип булсын.* М. Җәлил.

КӨЛКЕНЕЧЛЕ *с. к.* көлкенеч. [*Фәтхи*] *ничә еллар буенча шушы вакыйганы онытмады, исенә төшергән саен һәм кызганычлы, һәм көлкенечле тойгыларга бирелә иде.* Ш. Камал.

КӨЛЛЕ I *с.* Көл катнаштырылган, көл кушылган, көле булган. *Көлле туфрак астындагы кар күзгә күренеп әреде.* Г. Гобәй.

КӨЛЛЕ II *с. иск.* Барысы, һәммәсе; барлык. *Көлле яшел — каз тизәге булмас.* Мәкаль. [*Бабай:*] *Бу җыелып чыгуыгызның бөтен җәфасы, көлле мәшәкате сиңа гына төшәр.* Әкият.

КӨЛЛЕК *и.* 1. Тәмәке төпчекләре һәм тәмәке көле өчен махсус савыт.

2. Каралты астында көл җыя торган урын; көл җыя торган тартма, әрҗә. [*Хан:*] *Олы Болгар ханы Ялгыз кызы Бибкәй Солтанны Чүплек башындагы көллеккә Төшерү өчен үстергәнме тагы?* Н. Исәнбәт. *Аның карашы көллек почмагында аунап яткан иске чиләккә төште.* С. Рафиков.

3. Көл җыю өчен мич авызындагы кечкенә култык.

4. Самоварның аскы өлешендә көл коелып төшә торган урын. || *техн.* Пар миче учагының колосник рәшәткәсе астындагы көл җыела торган урыны.

КӨЛЛЕЛЕК *и. махс.* Ягулыкта көлнең күпме булу дәрәҗәсе, күләме.

КӨЛЛӘҮ *ф. махс.* Тиренең йонын кою өчен аңа известь катнаштырып көл сибү. *„Кызыл күнче" заводында көлләү цехы өчен механикалаштырылган известь хәзерләү пункты салына.* Соц. Тат.

КӨЛСУ *с.* Составында уңдырышсыз аксыл төстәге туфрак булган, шундый туфрак катнашкан. *Андый структурасы булмаган көлсу туфракларны эшкәртү юлы белән яхшырталар.* СССР физ. геогр.

КӨЛТӘ *и.* 1. Урылган игеннең бер бәйләм итеп җыеп бәйләнгән сабаклары (башаклары белән бергә). *Көлтә бәйләү.* □ *Нәфисә үзе дә, бераз дулкынлана төшеп, барабан каршысына беренче көлтәне китереп салды.* Г. Бәширов. *Бер егет кибән башыннан көлтә ыргытып тора.* Г. Ибраһимов. || Бер бәйләм итеп җыелган үсемлекләр, үсемлек сабаклары. *Беркөнне ул - - - әрәмәлектән бер көлтә аллы-гөлле чәчәкләр җыеп килгән сестраны очратты.* А. Шамов. *Мичкә ягар өчен салам көлтәләр бәйләү, сыерны көтүгә чыгару, кич каршы алу кеби эшләр — һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.* Г. Тукай.

2. *күч.* Берәр чыганактан таралган бик көчле нур, очкын, ут һ. б. турында. *Ут көлтәсе.* □ *Утын әрдәнәләреннән кызгылт-көрән төстә ялкын көлтәләре күтәрелә.* К. Нәҗми.

Көлтә бавы — көлтә бәйләү өчен ашлык сабакларыннан яки чи чыбыктан ясалган бау. [*Нарспи*] *узышлый камыл арасыннан ике бөртек солы башагы алды, аны җәһәт кенә көлтә бавына кыстырды.* Г. Бәширов. **Көлтә биргеч** *а.-х.* — молотилкада сугу аппаратына көлтә биреп торучы деталь. **Көлтә бәйләгеч** *а.-х.* — ашлыкны үзе урып, үзе көлтә итеп бәйләүче авыл хуҗалыгы машинасы. **Көлтә койрык** — йоннары күпереп торган зур койрык. *Төлке, төлке, туктасана, - - - көлтә-көлтә койрыгың селкә-селкә, син бүген кич сәфәргә барамсың?* Ф. Бурнаш. **Көлтә тигезләгеч** *а.-х.* — ашлыкны урып, көлтә итеп бәйләүче машинада сабакларны тигезләп торучы деталь.

◇**Көлтә шикелле (җиргә) аву (егылу)** — бөтен гәүдә белән бик каты егылу, барып төшү. *Поп көлтә шикелле җиргә ауды.* Ш. Усманов.

КӨЛТӘЛӘНДЕРҮ *ф.* Көлтә сыман рәвешкә китерү, көлтә сыман рәвеш бирү (мәсәлән, чәчкә). [*Хәят*] *тәртипсез булып бөтен гәүдәсе өстенә таралган чәчләрен яңадан бер кат ипләп кенә көлтәләндереп куй*[*ды*]. Ф. Әмирхан.

КӨЛТӘЛӘНҮ *ф.* Көлтә сыман булып сузылу, көлтә сыман рәвеш алу (нур, очкын һ. б. ш. турында). [*Сәлим*] *фонарьның көлтәләнеп алга сузылган яктысы белән бөтен бүлмәне капшап чыкты.* Г. Гобәй.

КӨЛТӘЛӘҮ *ф.* 1. Көлтә итеп бәйләү, көлтәләр ясау. *Кичкырын булганлыктан, мал астын кararга, салам көлтәләргә дип, ишек алларыбызга кереп киттек.* Ш. Маннур.

2. *рәв. мәгъ.* **көлтәләп.** Аерым көлтәләр белән, көлтәләргә аерып. *Шәмси бабай белән Гайни карчык киртә буендагы тарыларын бергәләп барып уралар, аны кыш буена аяз көннәрдә кием җәеп кенә көлтәләп сугалар.* Г. Ибраһимов.

КӨЛТӘЧЕ *и.* 1. Көлтә бәйләүче. *Көлтәче җырына кушыла елгалар.* Ә. Ерикәй.

2. Көлтә ташучы. *Шушы вакытта басу капкасында беренче көлтәче күренде: ул тау кадәр итеп төягән, һәм аты көчкә-көчкә тартып килә.* И. Гази.

КӨЛТӘЮ *ф. диал. к.* кылтаю. [*Сария түти*] *Варисның тормыш турында, килачәк турында уйламыйча, укыйм дигән булып борын чөеп, ачка көлтәеп йөрүенә каршы иде.* М. Хәсәнов.

КӨЛЧӘ *и.* Әче камырдан табада пешерелгән ашамлык; кабартма (элек көлдә пешерелгән). *Ач чагында биргән көлчә Тук чагында биргән калачтан артык.*

Мәкаль. *Әни безне көтеп торган икән, Икмәк салып, көлчә пешереп.* Ш. Маннур.

КӨЛӘҪ *с.* Елмаюлы, ягымлы, шатлыклы (йөз, күз һ. б. турында). *Аның көләч йөзенә карап, шатлыгының тышка бәреп чыкканлыгын бик тиз күрергә мөмкин иде.* М. Гали. *Матур гына зәңгәр көләч күзләре һәм балыкныкы төсле авызы белән ул шаян балаларга охшый төшә.* Ш. Камал. || Ачык йөзле, мөлаем (кеше турында). *Аның күз алдына һәрвакыт диярлек шат, көләч, ягымлы Гайнулласы килеп басты.* А. Әхмәт.

КӨЛӘҪЛЕК *и.* Ягымлы булу, ачык йөзле булу, мөлаемлык. *Комбайн кузгалуга, Василий дәдәнең йөзендәге көләчлек югалды.* Г. Гобәй.

КӨЛӘҪЛӘНҮ *ф.* Йөз ачылу, мөлаемлык барлыкка килү (йөздә), ягымлылану (йөз). [*Балаларын*] *күрү белән байларның йөзләре көләчләнде.* М. Гафури.

КӨЛҮ *ф.* **1.** Шатлану, күңел ачылып китү, канәгатьләнү һ. б. ш. хәлләрнең билгесе буларак, сулыш хәрәкәтләре тарафыннан барлыкка китерелә торган өзек-өзек кыска авазлар чыгару (кайвакытта нервларның кинәт бик нык какшавы белән дә бәйләнгән була). *Кызлар бер җиргә өелләр, үзләре чырык-чырык көләләр.* М. Фәйзи. *Шат алар, көлә барысы да — Куана шуңа күңел.* Ә. Исхак.

2. Шатлык, күңеллелек белдерү; канәгатьләнү белдерү (күзләр, йөз турында). [*Зөбәйдә*] *һаман көлеп йөргән зур күзләрен Канлы яшьләр белән тутырды.* Һ. Такташ. *Солдатның авызы ерылды, күзләре көлә иде.* Ш. Камал. || *күч.* Яктырту, матур караү, нур сибү (кояш турында). *Зур тәрәзәләрдән карап көлгән кояш та ничектер бүген бик әкрен тәгәри.* А. Шамов. *Кояш көлә, җылы нурлар сибеп, Болыннарны нурларга чорнап.* Ә. Ерикәй.

3. Мыскыллау, мәсхәрәләү; мәсхәрәләп көлү, мыскыллап көлү; кире мөнәсәбәт күрсәтү, түбәнсетеп карау. *Дуслар!.. Әгәр ямьсез вакыт килсә, хәзер миннән көләргә сез.* Г. Тукай. [*Хәмидә:*] *Мине һаман мыскыл итәсең, мин сиңа чынлап сөйлим, ә син һаман миннән көләсең.* Г. Камал. || Мыскыллау белдерү, кире мөнәсәбәт белдерү (күзләр, йөз турында). [*Габдулла*] *тыңлар-тыңламас, кырын-мырын утырган шәкертләрнең, үзенә ышанмыйча, көлеп караган күз карашлары астында* [*сүзен*] *дәвам итте.* Ә. Фәйзи. || Тәнкыйтләү, тәнкыйть итү. *Автор анда муллаларның һәм байларның алтынга алданып, саташып йөрүләреннән көлә һәм аларның никадәр ач күзле, кансыз икәнлекләрен күрсәтә.* М. Гали.

◇ **Көлеп карау** — игътибар итмәү, җиңел карау, санга сукмау, санламау; җитди карамау. *Меңнәрчә кешеләрне күп еллар буенча тәрбияләүче, үзенең һәр җөмләсе, һәр сүзе өчен җаваплы язучыларыбызның әдәби традицияләренә көлеп карыйбыз.* Һ. Такташ. **Көлеп тору** — бик матур булып күренеп тору, ялт итеп тору. *Газета чыннан да чиста эшләнгән иде, көлеп тора иде.* Г. Ахунов. *Яшеллек арткан, яңа өйләр, яңа капкалар күп. Урамнар көлеп тора.* А. Сәләхетдинов.

КӨМЕШ *и.* **1.** Аксыл соры төстәге ялтырап торган затлы металл, химик элемент. [*Пәкенең сабы*] *фил сөягеннән, көмеш белән бизәкләнеп эшләнгән бит.* Д. Аппакова. *Вөҗданымны сатмыймын алтын, көмеш һәм әнҗәгә.* М. Гафури. || *с. мәгъ.* Көмештән ясалган, көмеш кушып ясалган; көмеш йөгертелгән. *Әпипә яшел кашлы көмеш йөзек кигән кыска бармагы белән ялкау гына орлык чүпли-чүпли --- көлеп куйды.* Г. Бәширов. *Сәлим, кесәсеннән көмеш тәмәке савыты чыгарып, авызына папирос капты.* Г. Әпсәләмов.

2. Төп состав элементы көмештән яки никельдән гыйбарәт вак акча. *Аннан байтак кына көмешләр, бакырлар һәм берничә кәгазь акча килеп чыкты.* К. Нәҗми. || *с. мәгъ.* Төп состав элементы көмештән яки никельдән гыйбарәт, шуларның эретмәсеннән ясалган (акча турында). *Көмеш акча.* □ *Хисами кесәсеннән бер уч алтын, көмеш тәңкәләр чыгарып Хәйринең алдына куйды.* Г. Минский. || *с. мәгъ.* Көмеш тәңкәләр белән бизәлгән; көмеш тәңкәләрдән ясалган. [*Гайшә*], *ике көмеш чулпы белән дүрт беләзегеннән башка һәммә әйберләрен ташлап, Фәхригә ябышып чыкты.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Үзенең төсе яки ялтыравы белән шушы металлны хәтерләткән нәрсә, аксыл соры нәрсә. *Миңа күп кирәкми: Тик назлы көлешең һәм сөеп сыйпавың Чәчемнең көмешен.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Төсе яки ялтыравы белән көмешне хәтерләткән, аксыл соры. *Югарыда көмеш болытлар белән бер биеклектә --- бөркет оча.* Ш. Усманов. *Көмеш ай яктысында зәңгәр төтенгә чорналган авыл күренә.* А. Алиш. || *с. мәгъ. шигъ.* Агарган, чал. *Җитеп килә аңа җитмеш яше, Җем-җем итә җитен сакал, көмеш чәче.* Г. Тукай.

4. *с. мәгъ. күч.* Яңгыравыклы, яңгырап торган, ачык тонлы (тавыш турында). *Кыз көмеш тавышы белән бер шаркылдап көлде.* Г. Гобәй.

Көмеш сәрви *бот.* — кедр агачының бер төре, ак кедр.

КӨМЕШ-АЛТЫН *җый. и. сөйл.* Көмеш һәм алтын кебек затлы металлар. *Ничә яуларда булган, күрмәгән ул [батыр] мондый күп малны, Асыл ташлар, көмеш-алтын белән тулган залны.* М. Гафури.

КӨМЕШКӘ *и. сөйл. к.* самогон. *Шәми --- бер чирек көмешкәсен, түтәрәм пешкән итен күтәреп мунчага китә.* Р. Төхфәтуллин.

КӨМЕШЛӘНҮ *ф.* **1.** Көмеш йөгертелү, көмеш белән каплатылу. *Өлкән өйнең артында көмешләнгән иярле сылу айгыр, көннең кызулыгыннан, йөрүдән тирләп, башын чайкап тора.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Агару, чалару (чәч турында). *Суд алдында чәче көмешләнгән Чал бер карчык, яшьле күзләрен Сөртә-сөртә, залның йөргенә Каннар белән яза сүзләрен.* Һ. Такташ. || Аксыл соры төс алу, аксыл соры төскә керү. *Матур төн, һич болыт юк, якты ай сирпә нурын җиргә, Көмешләнгән агач яфраклары ай яктысы берлә.* М. Гафури.

КӨМЕШЛӘҮ *ф.* Көмеш йөгертү, көмеш белән каплау; көмешкә ману. *Орденнар, алтынлап, көмешләп эшләнгән булсалар да, җиңел, ә аларның чын хуҗаларын югалту бик авыр һәм йөрәк өзгеч әрнүле иде.* А. Шамов.

КӨМЕШСЫМАН *с.* Көмеш төсенә охшаган, көмеш төсе шикелле, аксыл соры. [*Газинур*] --- *двигательнең биек, челтәрле башнясына, көмешсыман канатларының кояшта ялтыравына карап ала.* Г. Әпсәләмов. *Советлар Союзында китереп чыгарылган яңа токымнар: көмешсыман-вуаль, кара-көрән һ. б. кроликлар бигрәк тә кыйммәтле.* Зоология.

КӨМЕШТӘЙ *с.* **1.** Көмеш төсендәге, көмеш төсенә охшаган, аксыл соры. *Азык әзләп килгән вак балыклар, көмештәй ак тәңкәләрен ялтыратып, кечкенә койрыкларын күңелле селкетеп, ялт әчкә таба йөзеп киттеләр.* Г. Гобәй. *Шул вакыт күздән чыга тәгәрәп көмештәй яшьләрем.* М. Гафури.

2. *күч.* Яңгыравыклы, яңгырап торган, чыңлап торган (тавыш турында). *Көмештәй тавыш.* | *рәв. мәгъ. Көмештәй яңгырап чыга иде аның тавышы.* А. Шамов.

КӨМЕШЧЕ *и. иск.* Көмешне бизәкләп әйберләр ясаучы яки әйберләрне көмешләүче оста. [*Шибай картның*] *сәгать бавы өзелгән иде, көмешче киявен-*

нән аны эшләтте. Г. Ибраһимов. *Өчесенә дә, көмешчедән монограмма яздырып, алтынланган жетон бүләк итәргә карар чыгардык.* Каз. утл.

КӨМЕШЧЕЛЕК *и.* Көмешче булып эшләү, көмешче хезмәте. *Көмешчелек белән шөгыльләнү.*

КӨМ-КӨК *с. сөйл. к.* күм-күк. *Ах, ул чаклар шундый ерак калып, көм-көк томаннарга төрелгән.* Һ. Такташ. *Һәфисә яшен суккандай тынсыз калды, иреңнәре көм-көк булып күгәреп китте.* Г. Бәширов.

КӨМӘН *и. сөйл. к.* йөк II. [*Хәмдия:*] *Бу арада минем, әллә нишләп, күңелем болгана. - - - Гөлнисаттәйгә сөйләгән идем дә, синең көмәнең юк микән, ди.* Т. Гыйззәт.

КӨН *и.* **1.** Тәүлекнең бер өлеше, кояш чыкканнан башлап кояш батканга кадәрге вакыт, иртәдән кичкә кадәр булган ара; *киресе:* төн. *Яз җитсә, төн кыскарыр, көн озаер. Кояш та иртә чыгып, бик соң баер.* М. Гафури. || *с. мәгъ.* Көндезге, көнгә бәйләнешле. *Тәрәзәмнән кергән көн яктысы сүнеп бара.* А. Шамов.

2. Бер тәүлек — 24 сәгать дәвам иткән вакыт арасы. *Кем урлады дисәм елларымны, Көннәр икән аның карагы.* З. Нури. *Менә ике көннән бирле инде Сөембикә дә фермада күренми.* Ә. Еники.

3. Нинди дә булса бер вакыт, айның яки атнаның бер көне. *Ә якшәмбе көн пионерлар, укытучылар җитәкчелегендә, зур хәзерлек белән өмә оештырдылар.* Г. Гобәй. || Нинди дә булса вакыйгага багышланган календарь дата, айның көне. *Танкистлар көне. Матбугат көне.* □ *Театрның ачылу көне бөтен театр халкының зур бәйрәме булып каршыланды.* М. Җәлил.

4. *күпл.* Нинди дә булса бер вакыт арасы, билгеле бер вакыт аралыгы. *Шул ук көннәрдә шәһәрдәге коймалар боерык кәгазьләренә күмелделәр.* К. Нәҗми. *Шулай бирә миңа яшәү рухын Синең хатың авыр көннәрдә.* Ә. Ерикәй. || Гомер. *Ватан өчен үзең теләп кабул иткән бу данлы үлем картлык көннәреңә кадәр булган утыз-кырык еллык тыныч хезмәттә үткән гомереңне каплый ала икән, мин иртә һәлак булдым дип кайгырырга һичбер сәбәп юк.* М. Җәлил.

5. *күч. иск.* Кояш, кояш яктылыгы. *Көн батканда күкне каплый Күкнең кызыл пәрдәсе.* Ә. Ерикәй. *Көн чыгар-чыкмас сабанга киткән ат, Җир сөреп кайтты авылга ул кабат.* М. Гафури.

6. *күч.* Тормыш. *Якты көннәр, зур бәхетләр эшләгәнлектән килә.* М. Гафури. *Алда күп әле эш Тагын көчне сынарга, колхозларны ныгытып, Таза көнгә чыгарга.* Ф. Бурнаш. || Бәхетле, яхшы тормыш. *Көн күрмәгән көн күрсә, көндез чыра яндырыр, тун күрмәгән тун күрсә, кага-кага туздырыр.* Мәкаль. [*Әпрәү:*] *Безгә дә көн килер әле.* М. Фәйзи.

Көн дә — көн саен. *Матурлык түйда кирәк, ә мәхәббәт көн дә кирәк.* Мәкаль. *Гайфи белән танышып алгач, Каюм, көн дә урамга чыгып, капка төбендә аның белән уйный башлады.* М. Гали. **Көн кичереш** *сөйл.* — тормыш, тормышны алып бару. *Яңа эзгә аяк баскан, демократик идеяләр белән сугарыла барган татар яшьләренең тормышына, көн кичерешенә күз төшереп үтик.* И. Рәмиев. **Көн тәртибе** — җыелышта, киңәшмәдә һ. б. тикшерелә торган мәсьәләләр, шул мәсьәләләрнең исемлеге. *Съездның көн тәртибендә төрле профессорлар, академиклар тарафыннан ясалырга тиешле зур фәнни докладлар тора.* М. Гали. **Көн уртасында (урталарында)** — төш вакытында, кояш төшлектә булган вакытта. *Көн уртасында сугыш үзенең иң кызу ноктасына җитте.* Ш. Усманов. *Көн урталарында урман өстендә җиңел зәңгәр нур балкып торды.* Г. Гобәй.

◇ **Көн ачылу** — яктыру, аязу. *Күзне ачып җибәргән вакытта көн ачыла төшкән, кар да явуыннан туктаган иде.* Х. Кәрим. **Көн(е) бетү** — яшәргә мөмкинлек калмау, авыр хәлгә калу. *Шуннан соң Таһиржән хәлфә тәмам күздән төште, көне бетте.* З. Һади. *Чебеннәргә моннан соң көн бетә.* А. Алиш. **Көн бозылу** — көн явым-төшемлегә әйләнү. **Көн булмау** — яхшы тормыш булмау; яхшы, иркен, тыныч тормыш белән яшәргә, эшләргә мөмкинлек булмау. *Җир тапмады ярлы игенчеләр, Көн булмады хатын-кызларга.* Ә. Ерикәй. **Көнгә калу, көненә калу** — нинди дә булса бер авыр хәлгә төшүне белдерә. [*Әхмәт:*] *Шулар аркасында мин бу көнгә, мәсхәрәлеккә калдым.* Г. Камал. **Көнен көнгә катып** — көнетөне, һәрвакыт, бертуктаусыз. *Эшләсә дә көнен көнгә катып, Яхшы юлга барып төшмәде.* М. Гафури. **Көн итү** — *к.* көн күрү. *Нургали, башлыча хатыны Миңсылудан ишетеп, аларның үзара бик тату торуларын һәм гади, тыйнак кына көн итүләрен белә иде.* Ә. Еники. **Көн кебек ачык** — бик яхшы билгеле, бик ачык аңлашыла. *Мәсьәлә көн кебек ачык.* **Көн(е) килү** — киң мөмкинлекләр ачылу; тормыш җиңеләю. *Җиһаншаның көне килде, Таһиржән хәлфәнең башындагы хыяллар вә фаразлар барчасы Җиһаншага күчте.* З. Һади. **Көн кичерү** — *к.* көн күрү. [*Эшчегә*] *берничә еллар буе төрле завод-фабрикаларда эшләп көн кичерергә туры кил*[*гән*]. Г. Нигъмәти. **Көн күзе йомылу** — караңгылану, караңгылык төшү. *Мөәзин сыман кеше хәлфә кулындагы таякны барып тотмаса, ихтимал, көн күзе йомылганчы җырлардар иде.* Х. Кәрим. **Көн күрсәтмәү (бирмәү)** — яшәргә мөмкинлек бирмәү, бик начар мөгамәлә күрсәтү. [*Фазыл:*] *Шаһбаз, ул җиңгән барыбер көн күрсәтмәс, син бездә кал.* Г. Ибраһимов. *Ә инде тычканнарга песи абзый көн бирми.* А. Алиш. **Көн күрү** — 1) яшәү, тору, гомер итү. — *Аталары чибәр генә көн күрәләр — атлы-сыерлы кешеләр.* А. Шамов; 2) үзеңнең яшәвеңне тәэмин итү, яшәү чыганагын табу; нәрсәне дә булса үзеңә кәсеп итеп алып, шул кәсеп белән яшәү. [*М. Гафури*] *шәкертлек дәверендә җәйләрен читкә китеп, байларга ялланып, ялчылык белән көн күрә.* М. Җәлил. **Көнне төнгә ялгап** — көне-төне, бертуктаусыз. [*Миңнурый:*] *Көнне төнгә ялгап, Бөгелмәгә ашлык ташыйбыз.* Г. Әпсәләмов. **Көннеке көнгә бетү** — 1) көн саен эзерләнгән, эшләп табылган яки һәр көн өчен билгеләп куелган азыкның, акчаның бетә баруы турында. [*Ифрат:*] *Тик алай да салам - - - көннеке көнгә бетеп бара, бер дә запас хәзерләп булмый.* А. Расих; 2) бер көнгә билгеләнгән эшнең, нормаңның төгәлләнеп баруы турында. **Көннекен көнгә теркәү (язу)** — көн саен башкарылган эшне һ. б. теркәп бару. *Тимери колхозның ашлыкны күпме тапшыруын көннекен көнгә шунда теркәп барды.* Г. Бәширов. **Көннекен көнгә җиткерү** — көн саен әзерләнгән, эшләп табылган яки һәр көн өчен билгеләп куелган азык я акчаны шул көнгә җиткереп бару, икенче көнгә калмавы турында. [*Газизә апага*] *көннекен көнгә җиткерер өчен әллә ниләр уйлап табарга, тормышны хәйләләргә туры килде.* Ә. Фәйзи. **Көнең төшү** — кемгә дә булса берәр үтенеч белән мөрәҗәгать итәргә туры килү. — *Аларга көнең төшсә, шулай булыр инде... Өч самоварлары бар, шуларның берәрсен чәй эчкәнче биреп торсалар, ашалыр дип курыкканнардыр!* М. Гафури. **Көннең көн буена** — бөтен көн дәвамында, озак. *Көннең көн буена утырып оешкан өгъзаларының нервлары тыныч-ланып, [Хәлим] ятуга эреп китә торган булды.* Г. Гобәй. **Көннең кадагына сугу** — нинди дә булса эшне бик кирәкле вакытта башкару, шул вакытка туры китерү. *Эчке поэтик интонация,*

революцион пафос һәм „көннең кадагына" суга белү ягыннан да [*Такташ шигырьләре*] *Маяковский шигырьләре белән аваздаш.* Х. Хәйри. **Көннәрдән бер көн(не)** — бервакыт, бервакытны. *Шулай көннәрдән бер көн, почтальонга каршы йөгергәндә, Илдар, әнесенең күңелен табарга теләп, юри артка калды.* Г. Гобәй. **Көннәре санаулы** — яшәү, тору яки гамәлдә булу вакыты күп калмаган. *Хәзер Вакытлы хөкүмәтнең көннәре санаулы дип карарга һәм монда да шуңа карап юл тотарга кирәк.* Ш. Камал. **Көннәрне авыштыру** — яшәү, тору. *Унбиш-уналты яшьләренә җиткәч, бу егет кырларга чыгып, урманнарга барып, кош-кортлар алып кайта икән дә, ди, болар шуның белән алай-болай итеп көннәрен авыштырып баралар икән, ди.* Әкият. **Көннәрнең берендә** — *к.* көннәрдән бер көн (не). *Көннәрнең берендә ул, Казаннан килгән бер уполномоченныйдан сорашып, Гали турында белешкән.* Г. Әпсәләмов. **Көн яктысын күрмим** *гади с.* — берәр нәрсәнең дөреслегенә ышандыру өчен әйтелә торган ант сүзе.

КӨ'НАРАЛАШ *рәв.* Бер көн аша, бер көн үткәч, бер көн үткән саен. *Екатерина Васильевна - - - көнаралаш чакырып әрли, нәсихәт укыган була.* Каз. утл.

КӨНБАГЫШ *и.* 1. Җимешләре зур тәлинкә сыман түгәрәккә урнашкан, орлыгыннан май алына торган, озын сабаклы, әре сары чәчәкле үсемлек. *Көнбагыш басуы. Көнбагыш сабагы.* □ *Көнбагыш кояшка гашыйк булып, аның артыннан көннең көн буе башын бора биреп карап торган кебек, Газинур да һәрвакыт Гали абзыйга таба борылып-борылып карый.* Г. Әпсәләмов. *Ерак та түгел, арыш арасында, ялгыз көнбагышның сары башы күренә.* И. Гази.

2. Шул үсемлекнең кабыклы орлыгы, җимеше. [*Тәкъва Сәхәүнең*], *көнбагыш ярганны яки сагыз чәйнәгәнне күрсә, „әдәпсезләнеп, авыз күтәреп, урамда ашап йөрмәгез" дип, колакны тартып киткән чаклары да еш була иде.* М. Әмир.

Көнбагыш мае — көнбагыш орлыгыннан алынган май, көнбагыш орлыгыннан чыгарылган май. *Фәриха суганлап, борычлап, көнбагыш мае белән примуста чыжылдатып бәрәңге котлетлары куыра.* Ш. Камал.

КӨНБАТЫШ *и.* 1. Дөньяның дүрт ягының берсе: горизонтның көнчыгышка капма-каршы булган, кояш баткан ягы. *Болыт үзенең өзгәләнгән чабуларыннан җиргә соңгы тамчыларын тамызды да әкрен генә көнбатышка таба йөзеп китте.* Г. Гобәй. *Өч көн инде, өч көн туктамыйча, Көнбатышка таба барабыз.* Ә. Ерикәй. || *с. мәгъ.* Көнбатышта булган, көнбатышка урнашкан. *Көнбатыш районнар. Көнбатыш чиктә.*

2. *(баш хәреф белән языла).* Көнбатыш Европа, Көнбатыш Европа илләре. *Көнбатышта ирекле шигырьне яклап, шуның буенча язып чыгаручыларның күпчелеге революциячел бунтарь, вак буржуа шагыйрьләре булдылар.* Г. Нигъмәти. || *с. мәгъ.* Көнбатыш Европаныкы булган, Көнбатыш Европага караган, аңа бәйләнешле. *Көнбатыш әдәбияты.* □ [*Г. Камал*] *Октябрьдан соң да әдәби тәрҗемәчелек эшен дәвам иттереп, рус һәм Көнбатыш классикларының күп кенә әсәрләрен татарчага күчерде.* М. Гали. [*Гөлшат:*] *Бөтен Көнбатыш инженерлары кулы белән салынган тимер-бетон ныгытмалар көлгә әйләнеп күккә очалар.* Т. Гыйззәт.

КӨНГЕ *с.* Билгеле бер көнгә караган, билгеле бер көндәге. *Ана күңеле йомшак, Ана күңеле Аяз көнге яңгыр шикелле.* Ф. Бурнаш. *Бүген балык та шактый мул пешкән, башка көнге кебек сыек өйрә генә булмыйча, ике табакта бутка кебек өелгән килеш өстәлнең башына куелган.* Ш. Камал. || *диал.* Көндезге, көндез була торган. *Көнге яктылыкта эшләп калу.*

КӨНГЕРӘ *и.* Сумкалылар семьялыгыннан арт аяклары озын, ал аяклары кыска, сикереп йөри торган имезүче хайван (Австралиядә, Яңа Гвинеядә яши). *Тыныч хәлендә көнгерә арт аякларына таянып утыра.* Зоология. || *с. мәгъ.* Көнгерә тиресеннән ясалган; көнгерә мехыннан тегелгән. [*Байгилде морза:*] *Пугачауның башы кылыч астында, уң кулы богауда. Сул кулын кискәнгә бер йөгерек ат белән бер көнгерә тун.* Г. Бәширов.

КӨНГӘ-КӨН *рәв.* Бер көнгә бер көн исәбе белән. [*Шәңгәрәй:*] *Җәй көне миңа көнгә-көн кулалмашка чыгарсың, кая үзем эшләп ташлыйм.* Г. Ибраһимов.

КӨНГӘ'ЧӘ *рәв.* Кайсы да булса бер көнгә кадәр. *Ул көннән бу көнгәчә бер ай тулды, икенчегә китте.* Ш. Камал. || Нинди дә булса бер вакытка кадәр, берәр вакытка чаклы. *Әдип Г. Ибраһимов бу әсәрендә Октябрь революциясе барышын башыннан алып хәзерге көнгәчә бөтен көйгә күрсәтүне өстенә йөкләми.* Г. Нигъмәти.

КӨНДЕЗ *и.* 1. Иртә белән кич арасындагы вакыт. *Июньнең башы, ап-ачык кояшлы көннең көндезе.* Ф. Әмирхан.

2. *рәв.* Иртә белән кич арасындагы вакытта. *Көндез палаталарга җылы кояш нурлары бәреп керә, ул аркаларны, кулларны, күкрәкләрне җылыта.* А. Шамов. *Йөрәгем яна минем, Яна көндез, яна кичен.* Ф. Кәрим.

КӨНДЕЗГЕ *с.* 1. Көндезгә караган вакыттагы, иртә белән кич арасындагы; көндез башкарылган, көндез эшләнгән. *Рифгать мәктәптән һәр көнне көндезге бердә кайтып керә.* А. Әхмәт. *Һава көндезгегә караганда җылына төшкән.* Ш. Камал.

2. Көндез уяу булган, көндез хәрәкәттә булган (хайваннар һәм бөҗәкләр турында). *Көндезге ертыкчылар. Көндезге күбәләк.*

Көндезге аш — 1) көн уртасында, төш вакытында оештырылган ашау. *Көндезге аштан соң корабтагы йөз дә уникә кеше барысы да бергә җыйналдылар.* А. Алиш; 2) шул максат өчен хәзерләнә торган аш, ашамлык. *Александра Андреевна белән Клавдия Степановна кунакларга көндезге аш әзерләп маташкан Бибигамбәр һәм Гөлбаһар абыстайлар белән исәнләштеләр.* М. Гали.

КӨНДЕЗГЕЛЕК *с. сөйл.* Көндезгә билгеләнгән; көндез куллана, файдалана торган. [*Бикбулат:*] *Менә атларга көндезгелек салам төйим дә, аннары кайтырбыз.* Г. Бәширов.

КӨНДЕЗЕН, КӨНДЕЗЛӘРЕН *рәв. к.* көндез 2. *Көндезен дә, кичен дә күп көч куеп тырышкач, корыч кошларны кабул итәр урын әзер була.* А. Алиш. [*Сәйфулла*] *хәтта авыл Советы йортына күчеп, шунда көндезләрен секретарь, төннәрен дежур булып торды.* Ә. Еники.

КӨНДИ'Н-КӨН *рәв. иск. к.* көннән-көн. [*Гыйльманов:*] *Авылда крәчин, шырпы, тоз шикелле әйберләрне алып булмый, калада да беткән дип сөйлиләр; икмәк хакы да көндин-көн күтәрелә.* М. Гали.

КӨНДӘГЕ *с.* 1. Көн дә була торган, көн саен кабатлана торган; һәрвакыттагы; гадәттәге. *Кояш яңа күк читтеннән күтәрелеп, үзенең көндәге эшенә — җирне пешерергә кереште.* Ш. Усманов.

2. Нинди дә булса бер сүздән соң килеп, эш яки хәлнең шул сүз белән тәгъбир ителгән конкрет бер вакытка караганын белдерә. *Бу көнге төн дә безнең өйдә үткән көндәге кебек күңелсез үтте.* М. Гафури. *Хәзер инде Фатыйманың ул чактагы төс-кыяфәте дә Мохтарның күз алдына килеп, беренче*

көндәге Фатыйма белән ике арада азмы-күпме охшашлык таба иде. Ш. Камал.

КӨНДӘГЕДӘЙ *рәв. к.* көндәгечә. *Көндәгедәй шатлык алып килә һәм шатлыгын җәеп туа таң...* Ф. Кәрим.

КӨНДӘГЕ'ЧӘ *рәв.* һәр көндәге кебек, һәрвакыттагы кебек, гадәттәгечә. *Көндәгечә Газизә абыстай кухняга аш өлгертергә чыгып китте.* Ф. Әмирхан. *Вахитов, көндәгечә, докторлык диссертациясе белән мәшгуль иде.* Ш. Бикчурин.

КӨ'Н ДӘ-КӨ'Н ДӘ *рәв.* һәр көнне, көн саен, гел. [*Полевод:*] *Минһаҗ агай, көн дә-көн дә буксирга тагылу ярамас бит, оятыгызга көч килмәсен дим!* К. Тинчурин.

КӨНДӘЛЕК I *и.* 1. Берәр кешенең төрле вакыйгалар һәм үзенең кичерешләре турында даими рәвештә язып барган язмалары, шәхси характердагы язмалар; шундый язмалар өчен билгеләнгән дәфтәр. *Соңга калып булса да, көндәлекнең кайбер урыннары белән таныш. Көндәлекнең кайбер урыннарын уку файда китерүе мөмкин.* Г. Кутуй. *Анри Барбюс сугышның бөтен якларын җанлы рәвештә күрсәтеп барган көндәлекләрен яза.* М. Җәлил.

2. Өйгә бирелгән эшләрне язып бару һәм билгеләр кую өчен хезмәт итә торган махсус дәфтәр. *Көндәлеккә өй эшләрен язып кую.*

Көндәлек дәфтәр — *к.* көндәлек I (1 мәгъ.). *Мин баламның көндәлек дәфтәрен язудан, язылганын укудан рәхәтлек таба идем.* Г. Кутуй.

КӨНДӘЛЕК II *с.* Һәр көн саен була яки башкарыла торган, һәр көн кабатлана торган. [*Шәргыя*] *йортның һәммә мәшәкатьләрен — сыер савумы, сарыкәҗә карауы, кыш көне бозаулар, бәрәннәр имезүме, утын кертү, су ташу, көндәлек аш пешерүме — һәммәсен җимереп эшли.* Г. Ибраһимов. || Һәр көн чыгарыла торган. *Язучы буларак чарлануда көндәлек газета миңа бик ныклы ярдәм итте.* Ф. Хөсни. || Гадәттәге, гадәти, бернәрсә белән дә аерылып тормаган. *Бу әсәрендә М. Гафури реаль сурәтләрдә ярлыларның көндәлек тормыш картинасын бирә.* Г. Нигъмәти. *Гыйззәт чәйханәдән чыкканда, шәһәр үзенең көндәлек төсен алган иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КӨНДӘШ *и.* 1. *иск.* Күп хатынлы ирнең хатыннарыннан берсе (алар бер-берсенә карата шулай аталганнар). [*Байның*] *йорты өч көндәшнең иртә-кич талаш, ызгыш, сугыш, чәч йолкыш белән үтә торган бер җәһәннәмгә әйләнде.* Г. Ибраһимов. | *с. мәгъ. Көндәш хатын шымчы булыр.* Әйтем.

2. Ире яки егете булган хатын-кыздан үзен яраттырган яки яраттырырга омтылучы кеше. [*Бакый:*] *Каушама, мирзам, назлы ярың булган Хәмдияңне сөюгә мин көндәш түгелмен.* М. Фәйзи. [*Газизов:*] *Бүлмәдә кемнәрдер пышылдашып сөйләшәләр. Берсе ирләр тавышы, әкенчесе — хатыным тавышы. Көндәшемне өзгәләп ташларлык булып, ишекне кискен генә ачтым.* А. Шамов.

3. Кемнән дә булса өстен чыгарга омтылучы, җиңеп чыгарга тырышучы. *Безнең гимнастларның төп көндәше Чехословакиянең бик яхшы спортчысы Вера Чславска булды.* Соц. Тат. [*Зәйнәпне*] *Каршы алды кояш ашкынып. Ул, әйтерсең, җиңгән көндәшенә Кызыл, матур байрак тапшырды.* М. Җәлил. | *с. мәгъ. Корпорацияләр һәм фирмалар асрый торган меңнәрчә шпиклар көндәш якның миллионнарча доллар торырлык производство серләрен кулларына төшерергә омтылалар.* Соц. Тат.

КӨНДӘШЛЕ *с.* Көндәш (1 мәгъ.) белән яшәгән, көндәше булган. *Усак яфрагы көндәшле хатыннар шикелле: җилсез көндә дә кыймылдап тора.* Әйтем.

КӨНДӘШЛЕК *и.* 1. *иск.* көндәш (1 мәгъ.) булу, көндәш булып яшәү. [*Ибрай:*] *Көнләшкән кызлар көндәшлеккә барсын.* М. Фәйзи.

2. Кемнән дә булса өстен чыгарга омтылу, кемне дә булса җиңәргә тырышу. *Капитал чыгаруның мөһим нәтиҗәләреннән берсе — державалар арасында көндәшлекнең үсүе, капитал салуның иң файдалы сфералары өчен көрәш.* Политэкономия.

КӨНДӘШЧЕ *и. к.* көндәш 3.

КӨНЕ-СӘГАТЕ *и.* Үз вакыты, тиешле вакыты. [*Шөҗаг:*] *Теләгән максатларыма җитәрмен, әле хәзергә тик көне-сәгате генә туры килми тора.* Г. Камал.

◇ **Көне-сәгате белән** — шунда ук, шул ук вакытта, бик тиз, һичкичекмәстән. [*Нәфисә*] *сүз уңаенда берәр шаян сүз әйтәме, иптәшләре арасында берәр вакыт җырлыймы—һәммәсен дә көне-сәгате белән, кибән хәтле күпертеп, каенанасына кайтып әләкләр.* Г. Бәширов.

КӨНЕ-ТӨНЕ, КӨНЕН-ТӨНЕН *рәв.* Көнен дә, төнен дә, берөзлексез. *Минем бүлмәмдә көне-төне буш вакытларын кая куярга белмәгән кешеләр җыелып яталар.* Ф. Әмирхан. [*Сәфәр:*] *Көннәр шулай аяз, кояш шулай нурлы булса, тагы атналар буенча, көнен-төнен туктамый эшләргә хәзермен.* Г. Ибраһимов.

◇ **Көнен-төнен белмәү** — көнен дә, төнен дә, ялсыз нинди дә булса эш башкару (бик ныклы бирелеп, үз-үзен аямыйча эшләү турында). *Шулай да егетләребез көнен-төнен белми бик тырышып эшлиләр, араларында ярышлар бик шәп бара.* М. Гали.

КӨНИТЕШ *и. сир. к.* көнкүреш. *Бу дәфтәрдәге җырларның да бер өлеше, табигый, хәзер телдән төшеп калган, онытылганнар. Әйтик, көнитештәге патриархаль карашларга бәйләнешле җырлар.* Н. Исәнбәт.

КӨНКҮРЕШ *и.* Тормышның гомуми рәвеше; билгеле бер халык, сыйныф, катлау яшәешенә хас гадәтләр, яшәү рәвеше. *Бу килүендә ул авыл хәлләрен, авылдагы, әйдүкләр кебек, ярлы кешеләрнең тормышларын, көнкүрешләрен сорашты.* Һ. Такташ. || Тормыш, яшәеш, көн күрү хәле. [*Бабай*], *көнкүрешләре бик начарланып киткәнлектән, җәяүләп Җаек суы буена барып, анда алпавытларга урак урып, печән чабып йөргәннәрен берәм-берәм бик озын итеп сөйләп бирде.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Көнкүрешкә караган, көнкүрешкә бәйләнешле. *Кешеләргә көнкүреш хезмәте күрсәтүдә вак-төякләр булырга мөмкин түгел.* Соц. Тат.

КӨНЛЕК I *и.* 1. Эш көне исәбеннән түләнә торган вакытлы яки сезонлы эш. *Эш эзләп көнлеккә килүчеләр бер минут эчендә бу усал кыяфәтле кешене әйләндереп алдылар.* М. Гафури. *Әнкәем Нурый хаҗиларда көнлектә йөри.* Г. Толымбай. || Шундый эшнең бер көне. *Конкрет иттереп алганда, эш хакы менә шул тирәдә: квалификацияле эшчеләр көнлеге—20—40 франк.* Г. Гали.

2. *сир.* Кеше үлгәннән соң билгеле бер көннәр үткәч, аны искә алу көне, искә алу йоласы (гадәттә саннардан соң килә). *Баязитның өч көнлеге уңае белән яшьләрне җыеп, кайбер турыда, бәлки, аңлашып та үтәргә булыр дип өметләнгәннәр иде.* Г. Ибраһимов.

КӨНЛЕК II *с.* 1. Бер көнгә билгеләнгән, билгеләп куелган. *Көнлек азык.* □ *Көнлек заданиемне түтыра алмадым. Ярышташларымнан калыштым.* М. Җәлил. || Сөйләмдә күрсәтелгән көн исәбенә җитәрлек, шул вакыт исәбенә билгеләнгән. [*Нәфисә*] *әллә ничә көнлек утыннарын ярып кертте, төн йокыларын калдырып, идәнен юды, керләрен*

уып китте. Г. Бәширов. *Шулай да семьяның дүртбиш көнлек расходы берьюлы китәсе беленде.* Ш. Камал.

2. Бер көн эчендә булган, бер көндә башкарылган яки башкарыла торган. [*Шиһаби*], *көнлек эш турындагы кыскача информацияләрен тыңлап, аларга да тиешле директиваларын биреп үтте.* М. Гали. || Сөйләмдә күрсәтелгән көн кадәр дәвам иткән яки итә торган, шул кадәр көннәргә сузылган. [*Закир:*] *Шул өч көнлек дөнья ләззәтләреңә алданып, нинди хурлыкларга төштем бит!* Г. Камал. *Ул бу шәһәргә берничә көнлек кенә эш белән килгән иде.* Ф. Әмирхан.

3. Бер көн эчендә җыелган, тупланган яки җыела, туплана торган. *Көнлек савым.* || Сөйләмдә күрсәтелгән көн эчендә эзерләнгән, тупланган; алынган. [*Мәликә:*] *Дткән белән миңа кечкенә самоварны, үзегезгә зур самоварны шаулатып җибәр дә дүрт көнлек каймактан май атларга тотын.* А. Шамов. || Бер көн эчендә эшләп алынган яки алына торган. *Көнлек эш хакы.* || Сөйләмдә белдерелгән көн эчендә эшләп алынган яки алына торган. *Биш көнлек эш хакы.*

4. *сөйл.* Көн саен чыга торган; көн саен гамәлгә ашырыла торган. *Көнлек газета.*

Көнлек дәфтәр—*к.* көндәлек I (1 мәгъ.). [*Нурулин:*] *Аның менә көнлек дәфтәрләре, хатлары, бер бик кадерле рәсеме Көньяк фронтында минем кулда калган.* А. Шамов. *Көнлек дәфтәрләр һәм истәлекләр язу кебек көндәлек элементар эшләрдә дә сөйләү теле кулланылмый.* М. Гали.

КӨНЛЕКЛЕ *с.* Эш көне исәбеннән түләнә торган (вакытлы яки сезонлы эштә). *Көнлекле эш.* □ *Урындагы крестьян хатын-кызларның көнлекле хезмәтенә сорау киңәя.* В. И. Ленин.

КӨНЛЕКЛӘП *рәв.* Эш көне исәбеннән түләп, эш көне исәбеннән түләү тәртибендә. *Без анда өч-дүрт көн чак кына ашарлык хак белән көнлекләп таш ташыдык.* Ш. Камал. *Без күршедәге Цызгановка көнлекләп ураккa йөри башладык.* Г. Бәширов.

КӨНЛЕКЧЕ *и.* Эш көне исәбеннән түләү шарты белән эшкә ялланган кеше (сезонлы, вакытлы эштә). *Балыкчы күлен мактый, көнлекче көнен мактый.* Әйтем. *Көнлекчеләр, шаулашып, көлешеп, ял сәгате җиткәнгә шатланышып, көндезге ашка кайтып киттеләр.* А. Шамов.

КӨНЛЕКЧЕЛЕК *и.* Көнлекләп эшләү. *Байларга урак уру, ашлык сугуларда күп тапкырлар көнлекчелектә бергә эшләгән дгъләм башта нык кына уйланды.* С. Рафиков.

КӨНЛӘП *рәв.* **1.** Көн исәбе белән, көн белән исәпләп. *Инде каушау көнләп түгел, сәгатьләп арта.* Г. Ибраһимов.

2. Үзеннән алдагы сан белдергән көн чамасында, чама белән шулкадәр көн дигән мәгънәне аңлата. *Газинурлар алгы кырыйга килгәннән соң ун көнләп вакыт үтте.* Г. Әпсәләмов.

КӨНЛӘШТЕРҮ *ф.* Көнләшү хисе уяту, көнләшү тудыру. [*Разия:*] *Син, егет, кызлар күргәч тә каш сикертмә алай. Карчыгыңны көнләштерерсең.* Р. Ишморат. *Башка кешеләрнең* [*Гомәрне*] *болай сөюләре, мактаулары бик үк көнләштермәсә дә, Мәрфуга апаның аны миннән артык сөюе мине борчый һәм бик кәефсезләндерә иде.* Ф. Әмирхан.

КӨНЛӘШҮ *ф.* **1.** Кемнең дә булса турылыгыннан, мәхәббәтеннән шикләнү, берәр кешенең мәхәббәттәге турылыгына, сафлыгына шикләнеп карау. *Мәдинәдән авылдагы байтак кына ирле хатыннар көнләшкән кебек, Батыршаның Мәйсәрәсе дә тыныч калмады.* К. Нәҗми.

2. Берәр кешедә яки әйбердә нинди дә булса өстенлек, уңай сыйфат, үзенчәлек яки уңыш күреп, шундый ук әйберне теләү, шундый ук сыйфатка, үзенчәлеккә, уңышка ирешәсе килү; кызыгу. *Сылу ханымнарның аяк йөзләренә кадәр салынып төшкән асыл ефәк халатлары, бер олтырактан гына торган әкәмәт туфлиләре* [*Нәҗияне*] *көнләшеп һәм көрсенеп уйланырга мәҗбүр итә.* Ә. Еники. *Ә теге ак күлмәкле малай, миннән көнләшеп, үзын китмәсен дип, терсәкләре белән әле мине этәргә, әле минем күлмәк итәгеннән тотып тартырга тотынды.* М. Гали.

3. Берәр кешенең нәрсәдә дә булса өстенлеген яки уңышын күреп гарьләнү, гарьлек, көнчелек хисе кичерү. *Мәфтуха бу кунак килендәшенең уңган кулыннан аз гына да көнләшмәде.* Г. Ибраһимов.

КӨНЛӘҮ *ф. сөйл.* **1.** *к.* көнләшү (1 мәгъ.). *Мәликә, илленең ар ягына чыккан булса да, картыннан әле һаман көнли иде.* А. Шамов.

2. *к.* көнләшү (2, 3 мәгъ.). [*Әлфинур:*] *Ул сугышта чакта аңа исәнлек-саулык теләдек... Ә ул безнең бәхетебезне көнли.* Р. Ишморат. *Аерылмас дуслыкны күреп, Дошманнар көнли бирсен.* С. Хәким.

КӨННӘ'Н-КӨН *рәв.* Торган саен, вакыт узган саен. *Революциянең яшь көчләре, көннән-көн күбәеп, алмаш сафларны тутыра баралар.* Г. Нигъмәти. *Ул көннән-көн матурлана, шаянлана, җитезләнә --- бара иде.* Ф. Әмирхан.

КӨННӘ'Н-КӨНГӘ *рәв. к.* көннән-көн. *Егет кеше көннән-көнгә алга баса, Башлаган һәрбер эшне тәмамласа.* М. Гафури.

КӨНОЗЫН *рәв.* Көн буе, бөтен көн дәвамында. *Таңнан торып, бакчада Син уйнадың көнозын.* М. Җәлил.

КӨН-ТӨН *рәв. к.* көне-төне. *Һөҗүмгә һәр минут хәзер булып тору өчен сугышчылар көн-төн кар көриләр.* Г. Әпсәләмов. *Садыйк соңгы көннәрдә үзенең эше артыннан көн-төн чаба.* Г. Ибраһимов.

◇ **Көнне-төнне белмәү**—*к.* көнен-төнен белмәү. *Язга хәтле, көнне-төнне белми, Тау кадәрле тозлар ташыдым.* Ш. Маннур. *Бөҗәкләр көнне-төнне белмәгәннәр, бар да тырышып савыт эшләгәннәр.* А. Алиш.

КӨНЧЕ *с.* **1.** Кемнең дә булса турылыгыннан яки мәхәббәттәге сафлыгыннан шикләнүче, кемнең дә булса турылыгына яки мәхәббәтенә шикләнеп караучы, көнләшүче. [*Ясәви:*] *Тик моны, җиңги, минем хатын күрмәсен әле, беләсең, ул бик көнче хатын.* Т. Гыйззәт.

2. Кемнең дә булса өстенлеген яки уңышын күреп гарьләнүче, шул кешедән өстен чыгарга теләүче. [*Һажәр:*] *Ялган, бары да көнче дошман сүзе генә.* Г. Ибраһимов. | *и. мәгъ.* [*Каплан:*] *Син алдыйсың, явыз көнче! Арабызны кылыч өзсен.* Н. Исәнбәт. || Көнләшүне белдергән. *Без ул тауның һәртөрле тискәре җилләрдән һәм очраклы кешеләрнең көнче карашларыннан яшерен, аулак җиренә урнаштык.* Ә. Еники.

◇ **Көнче күбәләк**—бик нык көнләшүчән кеше турында. [*Миңлениса:*] *Күзе гел кеше малында, көнче күбәләк.* Г. Минский. **Көнче яу** *иск.* — дошман явы, дошман гаскәре. [*Тугзак:*] *Туган илгә сөенче китердегез, Көнче яуга көенеч китердегез.* М. Җәлил.

КӨНЧЕЛ *с. к.* көнче. *Әнкәсенең хәзер генә шулай вак сүзле, кырыс чырайлы, көнчел һәм бәйләнчек каенанага әверелә баруы бик аяныч иде.* Г. Бәширов. [*Разия:*] *Гарьчел кеше син, Әнвәр. Көнчел, һавалы.* Р. Ишморат.

КӨНЧЕЛЕК *и.* 1. Берәр кешенең турылыгыннан яки мәхәббәтеннән шикләнү, тирән шомлану. *Сукыр көнчелек [Нәҗиянең] акылын томалый, әгәр Шакирының әнә очы кадәр генә хыянәтен сизеп калса, нинди ләззәт белән үч аласын уйлап хыяллана.* Ә. Еники.

2. Башка кешенең өстенлегеннән, уңышыннан көнләшү, гарьләнеп көнләшү хисе. *[Мәхмүзә:] Мәршидә турында чыгарылган берәр бәет --- колагыңа чалынып китсә, ышанма син аңа. Мәршидәгә үчләшеп, көнчелек белән генә язылган ул.* Р. Ишморат. *Калфакчы Сара кызының болай кинәт күтәрелеп китүе күпләрнең көнчелеген уятты.* Г. Ибраһимов.

Көнчелек килү — көнчелек туу, көнчелек барлыкка килү; көнләшү. *Кешенең яхшы эшенә көнчелегең килсә, аңардан уздырып эшлә.* Мәкаль. **Көнчелек тамыры**—көнчелек хисе, көнчелек тойгысы. *Көнчелек тамырлары хәрәкәткә килеп, Җиһанша хәзрәтнең күзен кан каплады.* З. Һади. **Көнчелеккә көч килү** — көнләшү, көнләшү хисе уяну.

КӨНЧЕЛЕКЛЕ *с.* Көнләшүле, көнләшүне белдергән. *Узган ел, төнге вакыйгадан соң, алар арасында көнчелекле киренке мөнәсәбәт урнашкан иде.* Г. Ахунов.

КӨНЧЫГЫШ *и.* 1. Дөньяның дүрт ягының берсе: горизонтның көнбатышка каршы булган, кояш чыккан ягы. *Ике тәрәзәсе белән көнчыгышка карап торган бу бүлмә аеруча якты.* Ә. Еники. *Көнчыгышта таңның беренче, әле оялчан һәм куркак яктысы сызылып килә.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Көнчыгышта булган, көнчыгышта урнашкан, көнчыгышка караган, көнчыгыштагы. *Көнчыгыш як.* □ *[Галләм:] Кызым көнчыгыш фронтында окопларда сестра булып йөри.* А. Шамов.

2. (*баш хәреф белән языла*). Көнбатыш Европа дәүләтләреннән көнчыгышка таба урнашкан илләр. *Пролетариат революциясе Көнчыгышны һәм иҗтимагый тарих баскычларының төрләрен өйрәнүне кирәк бер эш итеп мәйданга куя сәбәпле, --- бу әсәрне бераз төзәттем.* Г. Ибраһимов. || Капиталистик илләргә каршы буларак, Көнчыгыш Европадагы һәм Азиядәге социалистик илләр. || *с. мәгъ.* Көнчыгыш халыкларына хас, Көнчыгыш культурасына хас, Көнчыгыш халыкларына караган, Көнчыгыш белән бәйләнешле. *Көнчыгыш стиленда башкарылган декорация спектакльгә әкияткә хас --- нечкәлек биреп тора.* М. Җәлил. *Көнчыгыш тормышыннан алып картиналар язучы француз художнигы Бенжамен Констан картиналары бу музейда публиканың сөеп караган нәрсәләреннән икәнне әйтеп китәргә кирәк.* Г. Гали.

Көнчыгышны өйрәнү, Көнчыгыш гыйлеме—Көнчыгыш илләренең тарихын, экономикасын, телләрен, сәнгатен һ. б. тикшерә торган фәннәр; ориенталистика. **Көнчыгышны өйрәнүче** — Көнчыгыш турындагы фәннәр буенча белгеч, ориенталист.

КӨНЧЫГЫШТАГЫ *с.* Көнчыгышка урнашкан, көнчыгыш якта булган. *Бигрәк тә көнчыгыштагы туган республикаларда йөреп, аларның халык музыкасын гармонь аркылы бирүе белән Фәйзулла ага нык танылып җитте.* М. Җәлил.

КӨНЬЯК *и.* 1. Дөньяның дүрт ягының берсе: горизонтның төньякка каршы ягы. *Кич кояш иңгән вакытларда көньяктан сыекча болытлар күтәрелеп, бераз яңгыр да сибәләп алды.* Ш. Камал. *Җил көньякка борылды.* Г. Бәширов. || *с. мәгъ.* Берәр нәрсәнең көньягында булган, көньякка караган, көньяктагы. *Нәгыймә, киң баскычтан күтәрелеп, [коридорның] көньяк башына борылды.* Г. Ибраһимов.

2. *с. мәгъ.* Берәр урыннын (илнең, континентның һ. б.) шул юнәлештә урнашкан өлешенә караган. *Мин биредә, синнән ерак җирдә, Европаның көньяк кырында --- Хезмәт сөйгән бөек халыкны --- Ерткыч фашистлардан саклыймын.* Ә. Исхак. *Җәүдәтнең этисе элек көньяк өязләрнең берсендә комиссар булып эшләгән иде.* Г. Бәширов.

3. Җылы як, җылы климат полосасы. *Шул елларда күкрәк авыруы белән җәфаланып йөргән Горький, әсәрләрен бастырып, аз булса да гонорар алуны, дәвалану өчен көньякка — Кырымга китүне хыял итә башлый.* Г. Нигъмәти. || *с. мәгъ.* Җылы климат полосасына хас, шул полосага караган, шунда үсә торган. *Көньяк алмагачы.* □ *Көньяк табигатенең начар гадәтенчә, кинәт җил чыгып, ике яр арасында айкалып йөри башлады.* И. Гази. || *с. мәгъ.* Җылы климат полосасында яшәүче; көньякта яшәүче. *Кызгылт-көрән битендә итләч озын борын, озын кара мыегы, яшьләй агарган каты чәче белән ул көньяк халкына тартым кебек.* Г. Бәширов.

Көньяк полюс — Җир шарының иң көньяк ноктасы, көньякта Җир шарының әйләнү күчәре җир өслеге белән кисешкән урын. *Экватор Төньяк һәм Көньяк полюслардан бертигез ераклыкта тора һәм Җир шарын ике ярымшарга --- бүлә.* Физ. геогр.

КӨНЬЯК-КӨ'НБАТЫШ *и.* Горизонтның көньяк белән көнбатыш арасындагы ягы; шул яктагы урын. *Әгәр төньяк-көнчыгышка таба баргансыз икән, кире кайтканда көньяк-көнбатышка таба китәргә кирәк.* Физ. геогр. | *с. мәгъ. Көньяк-көнбатыш фронтның уң канатыннан башлап Румыния чикләренә кадәр булган урыннарда безнең гаскәрләр, бер-ике йөз чакрым алга кереп, бөтен Галиция һәм Буковинаны үз кулларына төшереп бетергәннәр иде.* М. Гали.

КӨНЬЯК-КӨ'НЧЫГЫШ *и.* Горизонтның көньяк белән көнчыгыш арасындагы ягы; шул яктагы урын. | *с. мәгъ. Урманның көньяк-көнчыгыш ягы.*

КӨНЬЯКТАГЫ *с.* 1. Көньякта булган, нәрсәдән дә булса көньякка урнашкан. *[Немецларның] көньяктагы гаскәрләре Ленинградны ерактан урап алу максатын үтиләр иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Җылы климат полосасындагы. *Күпмедер вакыттан соң ул үзенең көньяктагы бер шәһәрдә хезмәт итүен белдерткән иде.* Ә. Еники.

КӨНЬЯШӘР *и. зоол.* Яшәү гомере бер-ике көнгә сузылган канатлы бөҗәк; бер көнлек күбәләк; *русчасы:* подёнка.

КӨНӘГЕ *рәв. диал. к.* көнге. *[Хөсәен:] Үткән эш— үткән. Менә бу көнәгесен кararга кирәк.* Ф. Әмирхан.

КӨНҮЗӘК *с.* Билгеле бер вакыт өчен иң мөһим, бик кирәкле. *В. И. Ленин --- социалистик революциянең дәүләткә мөнәсәбәте турындагы мәсьәлә, --- „массаларга үзләрен капитал изүеннән коткару өчен якын киләчәктә нәрсә эшләргә тиешле булачакларын аңлатып бирү мәсьәләсе буларак, иң көнүзәк әһәмият казана" дип күрсәтте.* КПСС тарихы.

КӨНҖЕТ *и. иск.* Орлыгыннан май алына һәм игеп үстерелә торган көньяк үсемлеге. *Көнҗет мае.* □ *Ямәндә --- техник культуралардан көнҗет, индиго, босвелия --- үсә.* Каз. утл.

КӨНҖӘЛӘ *и. этн.* 1. Ике агач кисәген бер-беренә туры почмак ясап беркетеп эшләнгән, горизонталь кисәгенә утырып, вертикаль кисәгенең башына билгеле бер күләмдә йон бәйләп куеп, кул белән йон эрли торган җайланма. *Көнҗәләсе булмау сәбәпле, бу әби йонны урындык аягына бик олы иттереп яулык белән бәйли дә куя.* Әкият.

2. *с. мәгъ.* Эрләр өчен шул җайланмага бер мәртәбә бәйләп куелган яки бәйләп куярлык (йон). *Бер көнҗәлә йон.*

3. *күч. гади с. кимс.* Үзен пөхтә йөртмәгән, чәчебашы тузган ялкау хатын-кыз турында.

Көнҗәлә таягы — *к.* көнҗәлә (1 мәгъ.).

◇ **Көнҗәлә баш** *гади с. кимс.* — хатын-кызга кимсетеп әйтү сүзе. **Көнҗәлә койрык** — йоннары күпереп, кабарып торган койрык. *Биек нарат башында, аучыларга мыскыллы карап, көнҗәлә койрыклы тиен ботактан ботакка сикерә.* Г. Әпсәләмов. **Көнҗәлә сакаллы** — зур тузгак сакаллы. *Көнҗәлә сакаллы хөрәсәннең илгә нинди байлык тудырганы бар.* Г. Ахунов.

КӨПЕ *и. этн.* 1. Куй йоныннан сырып тегелгән бишмәт, тун кебек кием. *Бай, кунак белән сөйләнәсөйләнә, башындагы очлы бүреген, өстендәге көпесен салды.* Г. Ибраһимов. *Егетләрнең өченчесе, - - - көпесен аркасына яба төшеп, кырын ятты.* М. Гафури.

2. *диал. к.* көбә. *Дутанның угы, патшаның күкрәгендәге көпесеннән үтеп, аркасына тишеп чыкты.* Әкият.

КӨПКӘ *и. диал.* Малларны кышлату өчен җир асты абзары.

КӨПЧӘК *и.* 1. Күчәрдә әйләнеп, арбаларны, башка төрле йөртү чараларын хәрәкәткә китерә торган түгәрәк җайланма; тәгәрмәч (тешле яки тоташ була). *Велосипед көпчәге. Арба көпчәге. Вагон көпчәге.* ▭ *Атлар, тузанлы юл буйлап, ашыкмый гына, әкрен генә атлыйлар, алгы көпчәкнең берсе, елаган кебек, нечкә генә моңга чыелдый.* А. Шамов.

2. Төрле механизмнарда, машиналарда хәрәкәт барлыкка китерә яки аны тапшыра торган түгәрәк. *Пароход, үзенең кечкенә көпчәкләрен акрын гына әйләндереп, ашыкмыйча гына ярдан кузгалып китте.* Ф. Әмирхан.

Көпчәк бүкәне — көпчәкнең күчәр өчен тишеме һәм тешләр өчен оялары булган үзәк өлеше. **Көпчәк күтәрткеч** — арба майлаганда, ремонтлаганда һ. б. ш. очракларда күтәртеп тору өчен җайланма. [*Зәйнулла:*] *Арба майлаганда көпчәк күтәрткечне дә миннән кереп аласың бит.* Г. Галиев. **Көпчәк теше** — көпчәк бүкәнен тугым белән тоташтыра торган агач яки металл таяк, киге.

КӨПЧӘКЛЕ *с.* Көпчәк белән эшли, хәрәкәт итә торган. *Көпчәкле пароход. Көпчәкле трактор.*

КӨПЧӘКЧЕ *и.* Көпчәк (1 мәгъ.) ясаучы оста, һөнәрче. *Медынь өязе көпчәкчеләре.*

КӨПШӘ *и.* 1. Кисеме түгәрәк булган куыш эчле озынча предмет (гадәттә сыеклык, газ, пар һ. б. ны үткәрү өчен). *Әхмәт насос белән шанны тоташтырган тимер көпшәләрне зур газ ачкычы белән сүтеп маташа.* Ш. Камал. *Тимерче мичкәнең артына челтәрле озын көпшәләр беркеткән иде.* Г. Бәширов. ‖ *махс.* Гадәттә озын цилиндр формасындагы төрле приборларның һәм җайланмаларның исеме. *Ике нурлы көпшә. Электроник нурлы көпшә.*

2. Ату коралының пуляга яки снарядка юнәлеш бирә торган, торба рәвешендәге өлеше. *Пулемет көпшәсе. Туп көпшәсе.* ▭ *Узган көн солдат-солдат уйнап йөргәндә, малайлар ферма тиреслегеннән бер берданка көпшәсе тапканнар.* Г. Гобәй.

3. Кайбер үлән үсемлекләрнең турыга үскән эче куыш сабагы. *Кәҗәләр, елга кырыйларына, яр буйларына китеп, тал яфраклары, балтырган көпшәләре ашарга тотыналар.* М. Гали. ‖ *сөйл.* Шома көпшә. *Ул чагында, балтырганнан башка, какы һәм көпшәләр дә өлгерәләр.* Ак юл.

4. *бот.* Ботаникага караган кушма терминнарда икенче сүз (компонент) булып килә. *Аю көпшәсе. Шома көпшә.*

Көпшәгә китү — төпләнергә тиеш булып та, төпләнмичә сабак җибәрү (шалкан, кишер, чөгендер кебек үсемлекләр турында). **Көпшәгә утыру** — сабак җибәрү, сабаклану, сабак барлыкка килү (гадәттә игеннәр турында). *Көпшәгә утырудан соң күп тә үтми, югарыдагы яфрак җиңсәсеннән бодай башагы чыга.* Ботаника.

КӨПШӘК *с.* 1. Йомшак, күпереп торган, бөртекләнеп, таралып торган (кар, туфрак һ. б. турында). *Көпшәк туфрак.* ▭ *Аяз көннәр, каты суыклар булмаганга, кар бер дә катмый, яңа яугандай, көпшәк хәлендә тора.* Г. Ибраһимов. *Көпшәк токымнар барыннан да ешрак түбәнлекләрдә очрый.* СССР физ. геогр.

2. Тыгызлыгын, сыгылмалылыгын югалткан, бик йомшак, шәлперәйгән (мускуллар һ. б. турында). [*Әхмәди:*] *Нигә көпшәк тәнле син? Эшләми үскәнгә. - - - Менә шуңа күрә дә синең савырларың чүпрәк шикелле шәлперәеп кенә тора.* Г. Бәширов. ‖ Йомшарган, пәжегән; үз тыгызлыгын югалткан (яшелчә турында.) *Көпшәк шалкан.*

3. *махс.* Күзәнәкле, тишек-тошыклары булган. *Бу процесслар Ай диңгезләренең көпшәк каты өслекләре барлыкка килүгә китергән.* Соц. Тат.

КӨПШӘКЛЕК *и.* Көпшәк булу. *Карның көпшәклеге.*

КӨПШӘКЛӘНДЕРҮ *ф.* Казып яки башка юл белән көпшәк хәлгә китерү, йомшарту. *Шытымнар чыккач, рәт араларын көпшәкләндерәләр.* Ботаника.

КӨПШӘКЛӘНҮ *ф.* 1. Күпереп (таралып) торган хәлгә килү, көпшәк хәлгә килү, йомшару (туфрак һ. б. ш. турында).

2. Тыгызлыгын, сыгылмалылыгын югалту, шәлперәю (тән, мускуллар турында). ‖ Йомшару, пәжү, үз тыгызлыгын югалту (яшелчә турында). *Карбызлар көпшәкләнү.*

КӨПШӘЛЕ: көпшәле суган — орлык бирә торган, сабак чыгарган суган.

КӨПШӘЛӘНҮ *ф.* Көпшәгә әйләнү, көпшә хасил итү (кайбер үсемлекләр турында). [*Җир өсте*] *куш йодрык кадәрле чәнечкеләр бизәгән шайтан таягы, ат буе булырлык кара әрем, картаеп катудан көпшәләнеп, орлыкланып беткән кәҗә сакаллары белән капланган.* М. Хәсәнов.

КӨПШӘЧЕК *и. бот.* Кечкенә, нечкә көпшә. *Серкә көпшәчеге.*

КӨПӘ-КӨНДЕЗ *рәв.* 1. Көн уртасында, яп-якты вакытта. [*Разведчикларның*] *көпә-көндез казачий станицага һөҗүм итү ихтималы берәүнең дә башына сыймады.* Ш. Усманов. *Көпә-көндез, һәммә халык яланда уракта чакта, патшадан фәрман килеп төшә.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. сөйл.* Ачыктан-ачык.

КӨР *с.* 1. Симез, таза (терлек турында). *Атлар көр. Олы юл белән җилдереп алга баралар.* М. Гафури. | *рәв. мәгъ. Фәһим карамагындагы яшь терлекләр тиз үстеләр, кышка көр керделәр.* Соц. Тат. ‖ *сөйл.* Симез, мае күп булган (ит турында). [*Зифа карчык:*] *Аша әле, Шәрифулла туган. Менә дигән көр иттән пешергән аш, токмачы да илгән бодай оныннан.* А. Шамов.

2. *сөйл.* Яхшы үскән, шәп (үсемлекләр турында). *Күп вакытны әүгамә фронтлардан әйләнеп колхоз хәлләренә кайтып төшә. Бу ун көндә кем ничек эшләгән? Кайсы бригаданың бодае көррәк.* Г. Бәширов.

3. *сөйл.* Күтәренке, шатлыклы; яхшы (кәеф, рух һ. б. ш. турында). *Көр күңелле, шаян табигатьле Газинур бу өйгә килеп кергәч шулай ук тиз үзгәреп китә торган иде.* Г. Әпсәләмов.

4. *сөйл.* Яңгыравыклы, ачык, көчле яңгырашлы (тавыш, аваз һ. б.). *Үзенең көр тавышы белән Каюм җырлап җибәрде.* Г. Гобәй.

Көр (көре) җир — ундырышлы җир, файдалы матдәләргә бай җир.

КӨРГЕЛӘҮ *ф. сөйл.* Самоварның күмерен үрләтер өчен торбасыннан берәр нәрсә белән өрдерү. [*Миңзифа*] *әле самоварын көргели, әле тоз китерә.* М. Әмир.

КӨРД *и.* Иранда, Төркиядә, Гыйракта, өлешчә СССРның көньягында яши һәм иран телләре системасындагы телдә сөйләшә торган халык атамасы; шул халыкның аерым бер кешесе.

КӨ'РДЧӘ *рәв.* Көрд телендә.

КӨРДӘШҮ *ф. сир.* Күмәк уеннарның кайберләрендә уенга катнашучыларның, ике төркемгә бүленү өчен, үзләренә яшерен исем кушып, узаман (төркем башлыгы) алдына килүләре турында. *Бу көрдәшкәндә уйнаучыларның үзләренә кушып килгән кушамат исемнәре гадәттә бик шигъри, ишле-кушлы сүзләрдән гыйбәрәт була.* Н. Исәнбәт.

КӨРЕ *и.* Туку станогында буй җепне күтәрү-төшерү өчен җеп әлмәкләр беркетелгән кыса. *Мин көре аркылы әнигә җеп биреп торам.* И. Гази. *Тәбәлдерек ачкан җеп карнында Чабак-соса уйнап югала. Һәм көреләр парлап биеп тора, „һап та һоп!" дип, кылыч кул чаба.* Ш. Маннур.

Көре кылычы — *к.* көре. — *Бик һәйбәтләп язмышның көре кылычы аша кичеп барабыз без, беләсең килсә.* Н. Исәнбәт. **Көре күзе** — көредә буй җепләр үткәрү өчен хезмәт итә торган җеп әлмәк.

КӨРЕЛЕ: көреле чүпләм — чүпләмләп сугылган әйбер (җәймә, ашъяулык, сөлге һ. б. ш.). *Моңа түбәндәге нәрсәләр керә: чүпләм сөлгеләр, көндәлек бит сөрткеч тастымаллар, зур сәкенең бер башыннан икенче башына җитәрлек көреле чүпләм.* Каз. утл.

КӨРЕНДЕ *и.* Елга яки диңгез өстендә шадраланып, чыгынкыланып, кырлы-кырлы булып туңган тигезсез боз.

КӨРКЕЛДӘҮ *ф.* Көртлекләр, күркәләр һ. б. ш. кошлар турында: кычкыру, тавыш чыгару. *Көртлекләр үзләре дә шул хакта күп көркелдәргә* (күч. мәгъ.) *яратмыйлар.* Ш. Маннур.

КӨРЛЕК *и.* Көр булу. *Мал көрлеге көтүчедән.* Мәкаль. *Көрлеккә түзмәсәң, хурлыкка түзәрсең.* Мәкаль.

КӨРМӘК: көрмәк тел — тотлыга торган, сүзләрне ачык итеп әйтә алмаган кешегә карата кулланыла.

КӨРМӘКЛЕ *с.* Теле көрмәкләнә торган. *Күреклегә күз иярер, көрмәклегә сүз иярер.* Мәкаль.

КӨРМӘКЛӘНҮ *ф. к.* тел көрмәкләнү. [*Зиннәт*] *уртада туктап, көрмәкләнгән теле белән: „Исәнме, философ", — диде.* Г. Бәширов.

КӨРМӘКЛӘШҮ *ф.* Билләрдән алышып көрәшү, әүмәкләшү. *Икенче секундта* [*Марат белән Илдар*], *җим өчен тартышкан чыпчыклар кебек, юл тузанында көрмәкләшә иделәр.* Г. Гобәй. *Балалар бер читтә сабан туендагы кебек йөгерештеләр, көрмәкләштеләр, кычкырыштылар, хәтта бер-икесе тукмаклашып та алдылар.* Ә. Фәйзи. || Билләрдән тотынышу. *Укытучы якынайган вакытта теге малайлар көрмәкләшеп алыша да башлаганнар иде.* А. Әхмәт.

КӨРМӘКЛӘҮ *ф.* Ычкынмаслык итеп махсус элмәк — төен белән бәйләү; бәйләгәндә шундый төен ясау. *Көрмәкләп бәйләүнең дә, элмәкләп бәйләүнең дә, чалыштырып бәйләүнең дә нәрсә икәнен яхшы беләбез.* Г. Галиев.

КӨРМӘЛӘНҮ *ф. диал. к.* көрмәкләнү. *Миңа нәрсәдер мыңгырдады, теле көрмәләнеп беткән иде.* А. Таһиров.

КӨРМӘЛҮ *ф. сөйл. к* көрмәкләнү. *Эндәшә алмыйм — телем көрмәлә.* Н. Фәттах. *Чын сүз әйтүчегә Дөнья тар, тел көрмәлә, „Бетсен сугышлар!" дисәң, Ябалар тотып төрмәгә.* М. Гафури.

КӨРПӘ I *и.* **1.** Яңа туган сарык бәрәне.

2. Шундый бәрән тиресеннән махсус ысул белән эшләнгән мех, илтер. | *с. мәгъ.* Шундый мехтан тегелгән. *Күркәмгә күз иярә, көрпә тунга чүп иярә.* Мәкаль.

3. Әченә мамык, дөя йоны һ. б. ш. салып сырып ясала һәм яту яки утыру өчен аска җәелә торган кечкенә түшәк. *Карый, түргә менеп, төрле чүпрәк кисәкләреннән җыеп тегелгән көрпә өстенә утырды.* М. Галәү. *Касыйм --- түрдәге йомшак көрпә җәелгән урындыкка барып утырды.* Р. Төхфәтуллин.

КӨРПӘ II *и.* **1.** Ашлык бөртекләрен он итеп тарткан вакытта вакланган кабыклардан, тышчалардан гыйбарәт чүп (онны иләгәндә гадәттә иләк өстендә кала). *Каюм да иптәшенең борчылганын сизә, мунчада бодай түгел, көрпәсе дә юк икәнен күреп тора.* Г. Гобәй. *Чоланнан көрпә алып чыктым да улак тутырып җирән кашкага бутап бирдем.* Г. Ибраһимов.

2. *неол.* Металл яки агач өстен кыру юлы белән эшкәртәндә барлыкка килгән тузан, вак бөртекләрдән гыйбарәт чүп; металл яки агач эшкәртү калдыгы. [*Мастерның*] *да бармаклары металл көрпәсенә буялган.* И. Гази.

◇ **Көрпә кушу** — арттыру, үзеннән өстәү; бераз ялганлау. [*Сушков:*] *Арттыра, бераз көрпә куша.* Ш. Бикчурин. **Көрпә баш** *тирг.* — аңгыра кеше турында. — *Алай каты йокламыйлар аны, көрпә баш! Бездә бит монда төрле халык, ни эшләгәннәрен карап бетерә алмассың!* К. Нәҗми.

КӨРРӘИ: көррәи әрыз *иск.* — Җир шары. *Капланган көррәи әрыз Кан белән, буылган төтенгә.* Н. Думави.

КӨРСЕНҮ *ф.* Нинди дә булса хисне, кайгыны белдереп озын һәм тирән итеп сулау яки сулыш чыгару. *Газинур тагын бер тапкыр тулган айга карап алды, Миңнурыен сагынып тирән генә көрсенде һәм баракка кереп китте.* Г. Әпсәләмов.

КӨРСИ *и. иск.* **1.** Терсәкләрне куярга култыксасы булган киң урындык, кресло. *Түрдә дәрес көрсисендә --- Җәләлнең угылы күзлегенең өс ягыннан каршысындагыларны дикъкать итә.* Г. Ибраһимов.

2. Патшалар утыра торган, бик купшы итеп зиннәтләнгән урындык, тәхет урындыгы. *Солтан* [*патша*] *ялгызы көрсидә ял итә.* Ф. Бурнаш.

3. Иске мәдрәсәләрдә парта хезмәтен үтәгән озынча тәбәнәк өстәл. *Мин* [*мәдрәсәдә*] *көрсиләр арасындагы тар юл буйлап, эти артыннан --- түргә уздым.* Г. Гобәй. *Безнең сыйныфта минем белән бер үк көрсидә Зариф исемле бер бала утыра иде.* Ак юл.

КӨРТ *и.* Җил себереп ясаган кар өеме. [*Нәфисә:*] *Күз ачмаслык буранларда, көртләр ерып, нигә кар тоттык?!* Г. Бәширов. || Калын кар катламы. *Уйсу җиргә кар яуса, Бил тиңентен көрт булыр.* Әйтем.

КӨРТИ *и.* Пиджак һ. б. ш. өс киеме эченнән киелә торган, мехтан яки сырып тегелгән җиңсез кием. *Профессор Фукс өстен чишенеп, муенына чуар ефәк яулык бәйләп, җиңсез сырган көртидән генә, аркасын кызу мичкә терәп скамьяда утырып тора иде.* М. Гали.

КӨРТЛЕ *с.* Көрт баскан. *Яшь чыршыда тиен тырмаша, Бүре үтә көртле юл аша.* М. Сөндекле.

КӨРТЛЕК *и.* Тавыксыманнар отрядыннан ите ашарга яраклы, шактый зур кыргый кош; кыр тавыгы. *Карга кардан курыкмас, Көртлек көрттән*

өрекмәс. Әйтем. *Аларга бик күп куян, көртлек әзләре очрый.* Г. Әпсәләмов.

КӨРЧЕК *и.* 1. Чүрәкәй уенында: җиргә сызылган түгәрәк яки шул түгәрәк хезмәтен үтәгән таш. || Башка төрле балалар уенында: нинди дә булса чикне белдергән сызык. *Йөгерү, качу өчен бер сызык киртәсе (көрчек) билгелиләр.* Н. Исәнбәт.

2. Нәрсәнең дә булса соңгы чиге, ахыры. *Кайәрләнгән сугыш ярасы соңгы көрчек куйган егеткә.* З. Мансур.

◇ **Көрчеккә терәлү** — нишләргә дә белмәү, аптырау; бер карарга килә алмау. *Җир өләшү дигәннәре бик четерекле эш икән. „Өләшүен өләшергә, әмма ничек өләшергә?“ — дип, көрчеккә терәлеп кала кешеләр.* Ш. Маннур. *Биктимер абзыйның да быел эше көрчеккә терәлде.* Г. Толымбай.

КӨРӘГӘ *и. диал.* Бал һәм кымыз әчетә торган кечкенә мичкә яки тәпән; бал яки кымыз белән табынга китереп куелган шундый савыт. [*Колый:*] *Күп булса, бер ярты көргә балын күтәреп эчкәнмендер, шуннан шул, чыксам — егылганмын.* Н. Исәнбәт. || Шундый савыттагы әчетелгән бал. *Көргә булса, кунакның күңеле булыр.* Мәкаль.

КӨРӘГӘЧЕ *и.* 1. Табында көрәгәдән әче бал яисә кымыз салып бирүче кеше.

2. *диал.* Табын башлыгы.

КӨРӘЙТҮ *и.* Симертү, ашатып тазарту, көр итү. [*Наташа*] *Аланбаш хатыннарының атларга үз сыерларының сөтен эчерүләрен, үз бәрәңгеләрен ашатып көрәйтүләрен сөйләде.* Г. Бәширов.

КӨРӘК *и.* Җир казу, кар көрәү һ. б. ш. эшләр башкару өчен хезмәт итә торган, киң яссы очлы, озын саплы корал. *Тимер көрәк.* □ *Галиулла Хәлимнән көрәкне алды, озак азапланып, карга тирән чокыр казыды.* И. Гази. *Галләм үзенең агач көрәген алып килде дә актарып кар көрәде.* Ш. Камал.

◇ **Көрәк сакал, көрәк кадәр сакал** — зур һәм киң сакал, бөтен бит киңлегенә үскән сакал. *Уйсулыкта үскән бодайлар арасыннан чыгып килгән Мәрдәнша бабайның башлап көрәк кадәр ак сакалы күзгә бәрелде.* Г. Гобәй. **Көрәк сакаллы, көрәк кадәр сакаллы** — зур һәм киң сакаллы, бөтен бит киңлегенә үскән сакаллы. *Көрәк сакаллы рус картлары башларын чайкап куялар.* Г. Әпсәләмов. **Көрәк оны** — тегермәндә ашлык тарттырган өчен тегермәнчегә яки тегермән тоткан оешмага билгеле бер күләмдә бирелә торган он. [*Шәмгунның*] *тегермәне тирә-яктагы бөтен көрәк оның үзенә җыяр иде.* А. Шамов.

КӨРӘН *с.* Дарчин яки кыздырылган кофе төсендәге; коңгырт, коңгырт төстәге. *Көрән чикмән. Көрән шәл.* □ *Җиһангир карт алып кайткан ул көрән ат башка хикмәтләр дә эшләп ташлады.* Ш. Камал. || *и. мәгъ.* Көрән төс; көрән буяу. *Алъяпкыч мандым көрәнгә, Көрән матур кергәнгә.* Җыр.

Көрән күмер — сыйфаты ягыннан торфка якын торган түбән сортлы ташкүмер, соры күмер.

КӨРӘНЛӘНҮ *ф.* Көрән төскә керү, төсе көрәнгә әйләнү. *Тырмачы малайлар, --- тыныч адым белән җир үлчәп йөрүче картлар, язгы җилдә көрәнләнә башлаган алсу битле таза кызлар... Менә кемнәр [Нәфисәнең] сугышчылары!* Г. Бәширов. || Көрән булып күренү. *Тик уртада Симетбаш юлының көрәнләнеп торган юл сызыгы ярылып кала.* Ә. Фәйзи.

КӨРӘНСУ *с.* Сыек көрән, беркадәр көрән. *Көрәнсу төс.* □ *Әнисеннән [баласына] бик аз нәрсә күчкән: күзләре зәңгәр түгел, көрәнсу, чәчләре сыек сары, җирән.* Г. Гобәй.

КӨРӘПӘЛӘ *и.* Капюшон, өс киеменең очлы башлыгы. *Килен, ишек катындагы агач чөйдә эленеп торган ирләр кожаның алып, җиңнәрен киеп тормыйча гына, көрәпәләсеннән башына элде дә, берни дәшми чыгып китте.* М. Әмир.

КӨРӘШ *и.* 1. Ике кешенең, көч кулланып, бер-берен егарга тырышуы, үзара алышуы, бер-берсен җиңәргә тырышуы. [*Мәдинә:*] *Нокта Вәлинең хәлдән таюы да минекеннән ким булмагандыр. Чөнки көрәшнең актыгына таба ул мине бернәрсә дә эшләтә алмый башлады.* Ш. Камал. || Кешенең берәр төрле хайванны тотарга, әләктерергә яки җиңәргә тырышуы. *Әләккән мал хәйләле яки үтә көчле иде, --- арканны сизүгә кире чигенде дә, котылып китеп, --- дулап чапты. Карлыгач, бу көрәшне йөрәк дулкыны белән кузәтеп, айгырның һәм җылкычының һәр икесенең тойгыларын үз эчендә кичерде.* Г. Ибраһимов. || *махс.* Ике кеше бер-бере белән тотышып алышканда көч һәм җитезлекне сынау өчен билгеле бер кагыйдәләр нигезендә алып барылган спорт ярышы, спорт уены. *Татарча көрәш.* □ *Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы — хатын-кызы, баласы-чагасы болынлыкка төштеләр. Көрәшләр, узышулар башланды.* Г. Тукай. || Нинди дә булса спорт ярышы. *Җиңел атлетика буенча ярышларны караучылар --- дөньяның биеклеккә сикерүче иң яхшы спортчылары арасында барган кискен көрәшне оныта алмаслар.* Соц. Тат.

2. Капма-каршы иҗтимагый төркемнәрнең, юнәлешләрнең һ. б. ш. хакимлеккә ирешү өчен, җиңеп чыгу өчен алып барган актив эшчәнлеге, аларның бәрелеше. [*Әсәрдә*] *вакыйга байлар белән ярлылар арасындагы көрәшкә нигезләнгән.* М. Гали. || Шул төркемнәргә, юнәлешләргә кергән аерым вәкилләрнең бәрелеше. [*Салахиев:*] *Фәхри белән Вәли Хәсәнов арасындагы көрәшне мин ике кешенең үзара ызгышуы гына дип карадым.* Г. Ибраһимов.

3. Нинди дә булса бер максатка ирешү өчен алып барылган эш, шуңа юнәлтелгән актив эшчәнлек. *Шәхси борчулар артка чигенде, икмәк өчен көрәш, фронтны тәэмин итү өчен көрәш һәркайда беренче урынга килеп басты.* Г. Бәширов. [*Тукай*] *фольклорны феодаль крепостнойлык калдыкларына көрәштә көчле коралларның берсе итеп алды.* Г. Нигъмәти.

4. Сугыш, бәрелеш. *Көрәш әле шактый кызу барган чакта, Үрге Кигәвенле ягыннан ЧОН отряды килеп чыкты.* Ш. Камал.

5. *махс.* Үсеш процессында капма-каршылыкларның бәрелеше (табигатьтә, җәмгыятьтә). *Табигатьнең иркен күкрәгендә Мәңге көрәш, мәңге хәрәкәт; Мәңге туу, Мәңге артып тору Белән бергә Үлем-һәлакәт.* Һ. Такташ.

6. *күч.* Бер-берсенә капма-каршы булган хисләр, омтылышлар һ. б. ның бәрелеше. *Хикәядә кешелектә булган „явыз“ һәм „яхшы“ холык көрәше пассив күзәтүче карашыннан килеп бер-беренә каршы куелган булса, [драмада] ике сыйныф арасындагы көрәш сурәтләндерелгән.* Г. Нигъмәти.

КӨРӘШ-СУГЫШ *и.* Сугыш, дау. [*Полковник*] *егерме сигез яшьлек фронтчы офицер чагындагы кебек җитез егетлек белән яңадан кара атка сикереп менде, көрәш-сугыш өчен түгел, изәр, бетерер, аяк астына салып, ат дагасыннан таптатыр өчен.* Г. Ибраһимов.

КӨРӘШ-ТАЛАШ *и. сөйл.* Капма-каршы характердагы иҗтимагый төркемнәр, юнәлешләр һ. б. ш. составына кергән вәкилләрнең яки аерым шәхесләрнең бәрелеше, көрәше. *Үзара көрәш-талаш.*

КӨРӘШТӘШ *и.* Нинди дә булса эшчәнлектә (мәсәлән, революцион эшчәнлектә) якын ептәш, бер идея, бер максат өчен бергә көрәшүче кеше. *В. И. Ленинның көрәштәшләре.* □ *К. Марксның ка-*

бере өстендә сөйләгән речендә Ф. Энгельс: „... ул үлде. Себер рудникларыннан алып Калифорниягә кадәр, бөтен Европада һәм Америкада аны хөрмәтләгән, аны сөйгән миллионнарча революцион көрәштәшләре аны елап озаталар...“ ди. Яңа тарих. || Кем белән дә булса ниндидер бер эштә бергә актив эшләүче, бергә актив эш алып баручы. *Тузан эчендә ашлык сугып яткан хатын-кызлар, җырлый-җырлый салам тарттырып йөрүче малайлар, салам селкүче кызлар күз алдына килә. Болары да [Хәйдәрнең] иптәшләре, аның көрәштәшләре.* Г. Бәширов. | *с. мәгъ. Чакыра ул үз янына Көрәштәш иптәшләрен.* Г. Хуҗиев.

КӨРӘШЧЕ *и.* 1. Алдынгы идеяләрнең җиңеп чыгуы өчен көрәшүче кеше, шул көрәштә актив катнашучы. *Бу залга тулган рус, чуваш, яһүд, татар вәкилләре—менә шул бөек армиянең бер отряды, партия юлбашчылыгы астында канлы сугышларны кичеп, ярлы авылдан, завод-фабрикадан күтәрелеп чыккан көрәшчеләр иде.* Г. Ибраһимов. *Шәриф Камал әдәбиятка менә шул реакция елларында килде һәм югарыда саналган алдынгы эре демократик язучылар сафына көчле бер көрәшче булып басты.* М. Җәлил. | *с. мәгъ. Күңелләре яңа фикергә авышкан, эчләреннән көрәшче эшчеләргә якынлык сизгән солдатлар арасында шушы сүзләр яшерен генә сөйләнеп үтте.* М. Гафури.

2. *юг.* Сугышчы, сугышта катнашучы (күбрәк революция эшендә актив катнашучылар турында). *Кырларында, һәрбер тавында—Бөек иле өчен сугышып үлгән Көрәшченең кабере табыла.* М. Җәлил. *Бу — партизан көрәшләрендә даны чыккан Урал көрәшчеләре булып, аларның исемнәрен ишетү белән рух тагын да күтәрелде.* Ш. Усманов.

3. Спорт ярышының бер төре булган көрәш белән шөгыльләнүче, шул ярышта катнашучы. *Исем казанган көрәшчеләр.* □ [*Егетләр*] *цирк көрәшчеләренә охшарга чын күңелдән азапланалар.* Ф. Әмирхан.

КӨРӘШЧӘ *и. диал. к.* керәшә. *Әле генә [Мәрьям] карап торган урыннар яр кырыендагы көрәшчә оялары кебек кенә булып күренә.* Г. Бәширов.

КӨРӘШҮ *ф.* 1. Бер-береңне куллар белән тотып алып егарга тырышу, җиңәргә тырышу. *Шулай да кайчакны [малайлар] балалыкка бирелеп, уенга мавыгып китәләр дә җир өстендә әүмәкләшеп көрәшә башлыйлар.* Г. Бәширов. *Иң әлек чатан Зыя белән бер түбән оч малае көрәшә башладылар.* М. Гали.

2. Капма-каршы иҗтимагый төркемнәрнең, юнәлешләрнең һ. б. ш. актив бәрелеше турында. *Революция дошманнары, тиз көндә үзләренең бетәселәрен белеп, соңгы көчләрен җыеп безгә каршы көрәшәләр.* һ. Такташ. [*Г. Ибраһимовның*] *үзен үзе онытып революция эшенә чумган дип бирелгән революционерлары да көрәшә, сөя, иҗтимагый эш рәтеннән тагын шәхес тормышы белән дә яши белә.* Г. Нигъмәти.

3. Нинди дә булса берәр максатка ирешү өчен актив эшчәнлек алып бару, тырышлык күрсәтү. *Без тынычлык өчен көрәшәбез, Без таң юлы белән барабыз.* Ә. Ерикәй. — *Безгә сәламәт балалар өчен, сау яшьлек өчен көрәшергә кирәк.* Р. Ишморат. || Нәрсәне дә булса юкка чыгарырга, бетерергә тырышу, шул юлда эш алып бару. *Рак авыруына каршы көрәшү.* □ [*Речьтә*] *ата кырмыскаларның үзе кадәр әйберне күтәрә алуы да, ата кырмыскаларның зур походларга баруы да, урман корткычларына каршы көрәшүләре дә, шуның белән үсемлекләргә ярдәм итүләре дә — бар да бар иде.* А. Алиш.

4. *юг.* Сугышу, сугышта катнашу. *Тугыз йөз унсигезенче елда Тургай далаларында көрәшеп йөргән Оренбург һәм Урал эшчеләре ул станцияне тиз генә онытачак түгелләр.* Ш. Усманов.

5. Тартышу, каршы тору; бирешмәү (нинди дә булса авырлыкларга һ. б.). *Бу юлы бер ялгызы дулкыннар белән көрәшеп баручы Мәрдән абзыйны инде атлы казаклар да күреп алдылар.* Г. Гобәй. *Зыя мохит белән ачыктан-ачык көрәшә алмый.* Г. Ибраһимов.

6. *күч.* Берәр кешедә теләк, хис һәм башкаларның бер-бере белән капма-каршы килүе, бәрелеше яки берәр кешенең нинди дә булса рухи хәлне җиңәргә тырышуы турында. *Берәр секунд үз-үзе белән көрәшкәннән соң гына Шакир бу тойгыны баса алды.* Ф. Әмирхан.

КӨРӘШҮ-АЛЫШУ *ф. к.* көрәшү (1 мәгъ.). [*Эш көтеп торган ярлылар*] *салкынлыкка чыдый алмыйча --- әрле-бирле йөгерәләр, бер-берсе белән көрәшеп-алышып та киткән булалар.* М. Гафури.

КӨРӘЮ *ф.* 1. Көр хәлгә килү, симерү (терлек турында). *Мал-туар көрәю.* || *сөйл.* Тулылану, тазару, симерү (кеше турында). [*Сафура:*] *Шәһәр икмәге килешкән үзеңә. Кара, нинди матурланып, көрәеп киткәнсең.* Т. Гыйззәт.

2. Ачык яңгырау, көчәю (тавыш турында). *Ярдан ераклашкан --- саен, шәкертләрнең тавышы көрәя.* Ә. Фәйзи.

КӨРӘҮ *ф.* 1. Кар, тирес һ. б. ш. нәрсәләрне көрәк белән алып яки казып читкә ташлау. *Сыер абзарының урта ишеге киң ачык, аннан тирес көрәп чыгаралар.* Ә. Еники. *Минһаж, --- киң агач көрәк алып, түй килгәнче тизрәк капкаларны, юлларны көрәргә чыкты.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. сөйл.* Нәрсәне дә булса бик күпләп алу, бик күпләп үзләштерү. [*Миңнулла:*] *Әмеркә дигән комсызы Себер алтынын үзе көрәмәкче була икән.* И. Гази. [*Вәлиев:*] *Тире-май җыеп, үзең авылдан авылга, базардан базарга чаптың. Көрәп акча алдың.* С. Рафиков.

КӨРҖӘ *и. диал.* Кечкенә балаларга яратып әйтелә торган сүз.

КӨС *и. диал.* Вак балык, маймыч. *Салих көсләрне әрли-әрли кармагына суалчан кигезде.* Г. Мөхәммәтшин.

КӨСМӘН *и. иск.* Зур ишкәк, койрык ишкәге (салларда һ. б. ш.). *Бот буе гына малай чагыннан ук көсмән тотып кул кабарткан Гаязның беләк[1] мускуллары уйный, күңеленә читтә чакта онытылып торган бер хис йөгерде.* Х. Сарьян.

КӨСТӘНҮ *ф. иск. к* көсәнү. *Көстәнеп күп егладым күңелем тулып.* Г. Кандалый.

КӨСӘМЧЕ *и. иск. диал.* Биләмче.

КӨСӘНҮ *ф. иск. диал.* Теләү, сорау, өмет итү. *Тимәсне көсәнүдән файда юк.* Мәкаль. *Авыр сулап бабай көсәнде, Тәңре, коткар, үзең ярдәм бир, дип, Күзен күккә таба күтәрде.* Г. Сөнгати.

КӨТ: көтә-көтә көт булу — *к.* көтә-көтә көтек булу (көтү I). [*Әгъзам:*] *Без монда көтә-көтә көт булдык.* Р. Ишморат.

КӨТЕК *с. сөйл.* 1. Начар, өтек; кимчелекле, җитешсезлекләре күп булган. *Көтек проект. Көтек тел.*

2. *кимс.* Кыска. *Көтек пальто.* □ *Көтегрәк койрыклы бу ак тавык үзенә йөкләнгән бурычны вакытында һәм бик төгәл үти иде.* Г. Галиев. || Тар, нечкә; өтек. [*Бәк Бәкичнең*] *ирене өстендә көтек кенә мыек, каш нечкәртелгән.* Х. Кәрим.

Көтек кишер *диал.* — кишернең нант сорты кайбер урыннарда шулай йөртелә.

КӨТЕКЛЕК *и.* Начар булу, җитешсезлекләре күп булу; начарлык. *Иптәш Плеханов буржуаз проект-*

ларның бу көтеклеге, бу кыюсызлыгы турында, кадетларның бу аумакайлыгы турында дәшми калып дөрес эшлиме? В. И. Ленин.

КӨТЕ'ЛМӘГӘН *с.* Кинәт килеп чыккан, алдан билгеле булмаган, очраклы рәвештә килеп чыккан. *Көтелмәгән бер хәл бу ике яшьнең тормышын бөтенләй бүтәнчә борып җибәрде.* Г. Бәширов. *Көтелмәгән кечкенә бер вакыйга Нургалинең күзен ачты.* Ә. Еники.

КӨТЕ'ЛМӘГӘНДӘ *рәв. к.* көтмәгәндә. *Көтелмәгәндә килеп төшкән үги килен бөтен мәҗлес вакытында гаҗәп дәрәҗәдә кирәкле кул булып китте.* Г. Ибраһимов. *Бигрәк көтелмәгәндә Гыйззәт абзый үлеп киткәч, Хәйретдин яшь калгач, аларның тормышлары тагын да начарланып китте.* М. Гали.

КӨТЕ'ЛМӘСТӘН *рәв. к.* көтелмәгәндә. *Бу шулкадәр көтелмәстән, уйламастан һәм шулкадәр табигый әйтелде ки, Рәхилә ихтыярсыз янә эченнән әле генә әйткән сүзләрен кабатлап куйды.* Ә. Еники.

КӨТЕПХАНӘ *и. к.* китапханә. *Клубларда, уку йортларында, көтепханәләрдә Ш. Камал иҗаты һәм совет әдәбияты темасына күргәзмәләр оештырыла.* М. Җәлил. [*Хәйров:*] *Мин үземнең көтепханәмне бик бай дип йөри идем. Ләкин бүген мин анда үземә иң кирәкле бер китапның юклыгын сиздем.* А. Әхмәт.

КӨТЕПХАНӘЧЕ *и. к.* китапханәче. *Аннары рус теле һәм әдәбияты кабинетында көтепханәче булып эшләвем дә үсүемә аз ярдәм итмәде.* Г. Кутуй.

КӨТЕШЛИ *рәв. сөйл.* Көтеп торганда; көтеп торган вакытта, көткән чакта. *Суд барган вакытта Нәгыймә, баласы авырганны ишетеп кайтканнан соң, аптекада дару ясалганны көтешли, Шәрәфиләр өенә кереп, мәҗлестә утыра.* Г. Нигъмәти.

КӨ'ТМӘГӘНДӘ *рәв.* Кинәт, һич уйламаган чакта, көтмәгән вакытта. *Көтмәгәндә кар-томаннан килде чыкты шүрәлем.* Г. Тукай. — *Көтмәгәндә безнең фатирга да бәреп керүләре мөмкин.* К. Нәҗми.

КӨТӘРГӘ *рәв. сөйл.* Бурычка, әҗәткә, соңыннан түләү, кайтару шарты белән (акча, әйбер алу). *Кайберләре, башкалардан унар тиенләп көтәргә алып, аны да оттырдылар.* М. Гали.

КӨТӘСЕГӘ *рәв. сөйл. к.* көтәргә. *Мәскәү һәм Варшава фабрикантлары көтәсегә --- мал саталар.* Ш. Мөхәммәдев.

КӨТӘЧӘККӘ *рәв. сөйл. к.* көтәргә. — *Орлыгың аз булса, көтәчәккә бирермен.* М. Җәлил.

КӨТҮ I *ф.* **1.** Кемнең яки нәрсәнең дә булса килүен яисә берәр нәрсәнең булуын алдан белеп саклап тору; очратырга, каршы алырга әзер булып тору. *Нижнийга барырга хәзерләнгән бик күп кешеләр вакытыннан соңга калган пароходны көтеп торалар иде.* Ф. Әмирхан. || Кемнең яки нәрсәнең дә булса килүенә яисә берәр нәрсәнең булуына исәп тоту, ышанып йөрү, шуны теләү. [*Хәйбулла:*] *Җәй көне Миңлегөл белән икәү без сезне бик көткән идек.* Ш. Камал.

2. Берәр нәрсәнең башкарылуына, үтәлүенә, булуына ышану, ышанып тору; шулай булыр дип уйлау. — *Без колхозчылар җыелышында алдан синең заявлениеңне көткән идек.* Ф. Бурнаш. *Бу юлы да шулай бераз әйткәләшеп алырлар да туктарлар дип көткән идек, ләкин алай булып чыкмады.* А. Шамов. || Нәрсәне дә булса бик ышанып өмет итү. *Җәйгә чыкса, һәр кеше бәхетен басудан көтә.* М. Гафури. *Без бу яшь таланттан совет татар музыкасы өчен тагын күп нәрсәләр көтә алабыз.* М. Җәлил. || Кем дә булса сүз әйтер, җавап бирер дип уйлау; берәр мәсьәләне хәл итәр дип өмет итү. *Үзеннән җавап көткән бу дәртле, кискен карашлы тынгысыз кызга Мансуров куаныч белән карап алды.* Г. Бәширов. || Нәрсәне дә булса теләү. *Сөйгән кызын көткән кебек, үсемлекләр яңгыр көтәләр.* Ә. Ерикәй.

3. Берәр кешенең килүенә (кайтуына) ышанып торып, билгеле бер вакыт уздыру. [*Сәйфулла:*] *Син бер ел көтә дә алмыйсың, шуңарга күрә бер айдан ук кайтам да.* Ф. Бурнаш. *Ул көнне Шаяхмәтне үз частенда бик озак көттеләр.* А. Әхмәт. || Берәр төрле эшнең, процессның башкарылуын, алда булачак берәр төрле эш яки хәлнең килеп җитүен саклап вакыт үткәрү. [*Габиш*] *агач төбенә утырып караңгы төшкәнне көтәргә булды.* Ф. Кәрим. [*Мостафин*] *сайлауларны көтәргә булды: ихтимал, шул чакта җәнҗалсыз гына* [*райком составыннан*] *төшеп калырмын дип өметләнеп торды.* Ә. Еники.

4. *гадәттә өченче затта.* Кем өчен дә булса әзерләнеп куелу, алдан билгеләнеп куелу; алда нинди дә булса эш тору. *Ул кызның чырае бик якты, чөнки аңар шәһәргә бару рәхәт, шәһәрдә аны шатлык көтә.* Ф. Әмирхан. [*Аны*] *эш өстәлендә өем-өем дәфтәр көтә иде.* Г. Гобәй. || Үзе өчен берәр нәрсә таләп итү, нинди дә булса бер хәлне теләү. *Олы улы хәзерләп калдырган юкә бүрәнәләр бик күптәннән бирле шуны көтеп яталар иде.* А. Шамов.

◇ **Көтмәгән җирдә(н)** — көтмәгән вакытта, һич көтмәгәндә, һич уйламаганда. *Ник хәзер* [*бай абзый*] *күңлең боек? Әллә һичбер көтмәгән җирдән сату туҡталдымы?!* М. Гафури. **Көтә-көтә көтек булу** — көтә-көтә арып бетү, көтә-көтә алҗып бетү. [*Хәмди:*] *Ул ир дигән нәрсәләрне көтә-көтә көтек булып бетәрсең.* Ш. Камал.

КӨТҮ II *ф.* **1.** Терлекләрне кырда, болында һ. б. ш. урыннарда йөртеп ашату, ашатып карап йөртү. *Атлар көтү.* □ [*Караборын*] *аның бергә сарыклар көтеп йөргән дусты, иң сөекле дусты әйдүк икәнен исенә төшерә алмады.* Һ. Такташ.

2. Күмәк уеннарның кайбер төрләрендә уенны алып бару, уенның төп эшен башкару (мәсәлән, качучыларны эзләү һ. б. ш.).

КӨТҮ III *ф.* **1.** *Дөнья көтү, тормыш көтү* тезмәләре составында килеп, „алып бару“ мәгънәсен белдерә. *Тормыш көтү.* □ *Мәдинә сигез яшьлек бала белән тол көе дөнья көтәргә кала.* Ш. Камал.

2. *иск.* Берәр эшне башкару, үтәү. *Мәдрәсәдә һәр көн бер шәкерт кизү көтә.* М. Гафури.

КӨТҮ IV *и.* **1.** Болында, кырда һ. б. ш. урыннарда бергә көтелә, ашатып йөртелә торган терлекләр төркеме. *Ат көтүе. Сыер көтүе.* □ *Көтүдән аерылган куйны бүре ашый.* Мәкаль. *Авылдан бераз киткәч тә, үләнле бер урында без көтүне таратып җибәрәбез дә, үзебез, тирес өеме янына барып, ут ягабыз.* М. Гали. || *сөйл.* Бергә туплап асрала торган хайваннар төркеме (бик күп, ишле төркем мәгънәсен белдерә). *Уразмановның бер көтү эте һәм этләреннән дә явызрак берничә приказчигы бар иде.* Г. Гали. || Кайда да булса асрала, үрчетелә торган авыл хуҗалыгы хайваннары. [*Районның*] *көтүләрендә моңа кадәр күрелмәгән яхшы нәселле әре терлекләр барлыкка килде.* Г. Бәширов.

2. Бергә тупланып яки бер төркем тәшкил итеп торган хайваннар төркеме, өере; нинди дә булса хайваннар, кошлар һәм балыкларның зур төркеме. *Тын урман өстеннән бер көтү кыр казы шаулап узды.* Г. Гобәй. *Юл өстеннән ач каргалар көтүе кузгалып очып китә.* Ә. Фәйзи.

3. *күч. сөйл.* Төркем, күп санлы кешеләр төркеме. *Бер көтү малай, тупырдашып, басу капкасына таба йөгерә иде.* И. Гази. || *кимс.* Өер, шайка. *Шул төндә эреп күккә очар Теткәләнгән фашист көтүе.* М. Җәлил.

Көтү башы — көтүне ияртеп, көтү башында йөрүче хайван. *„Көтү башы“ дип атап йөртә торган берничә сыер бар — карт, зур, мәһабәт, могтәбәр хайваннар --- алга чыгып, юлбашчылык кылалар.* Г. Ибраһимов. **Көтүгә куу** — терлекне көтүгә кушып жибәрү, башка терлекләр белән бергә көтүгә жибәрү. *Ике сыерны савып, эчереп көтүгә куарга, аннан кайткач ике бозауны да илтергә кирәк.* А. Шамов. **Көтү куу** — көтүне чыгарып жибәрү, көтүне кырга, болынга жибәрү. *Габденнасыйр да, беркөн иртән көтү кугач, атын арбага жигеп, хатынын, ике улын утыртты да Сәкел үзәне буендагы жирен урырга алып китте.* М. Гали. **Көтү сөрү** *диал.* — *к.* көтү куу. *Коммуна членнарының эйберләрен күчерү иртән көтү сөргән вакытларда булды.* Ш. Камал.

КӨТҮ-КӨТҮ *рәв.* Аерым төркемнәр тәшкил итеп, төркем-төркем булып. [*Зыя*] *көтү-көтү булып уйнаган малайларга катышмый.* Г. Ибраһимов.

КӨТҮЛЕК *и.* Көтү көтә торган жир, көтү йөртә торган урын. *Көтүлекләр төрле урыннарда була.* А. Расих. *Абзардан гына түгел, көтүлектән дә жыйдылар малайлар сыер тизәген.* Г. Гобәй.

КӨТҮЛӘП *рәв. сөйл.* Төркемләп, төркем булып, төркем итеп. *Кулларын муеннарына аскан яралы яшь егетләрне таза атларга менгән, мылтык, кылыч аскан калын жилкәле казаклар көтүләп алып киттеләр.* А. Таһиров.

КӨТҮЧЕ *и.* 1. Көтүне болынга, кырга һ. б. ш. урыннарга алып чыгып, карап, саклап йөртүче, ашатып йөртүче. *Абый да, мин дә көтүчеләрнең аркаларына котомка асып, озын чыбыркы өстерәп, иртә белән кояш күтәрелгәндә кычкыра-кычкыра бөтен авылның терлеген басуга алып чыгып китүләренә --- күптән кызыгып йөридер идек.* М. Гали.

2. Күмәк уеннарның кайбер төрләрендә уенны алып баручы, уенның иң төп эшен башкаручы. *Йөгерешле, качышлы һәм башка шуның шикелле күмәк уеннарда күп вакытта балаларга арадан берсен көтүче итеп сайларга туры килә.* Н. Исәнбәт.

Көтүче быргысы *муз.* — халык музыка коралы (агачтан ясала). **Көтүче бөтнеге** *бот.* — бөтнекнең бер төре. **Көтүче кубызы** *бот.* — гадәттә яр буйларында үсә торган күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* частуха. **Көтүче сумкасы** *бот.* — әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан артык биек булмаган сабаклы, ак чәчәкле һәм жимеше биштәргә охшаган кечкенә кузактан гыйбарәт үсемлек; *русчасы:* пастушья сумка. *Көтүче сумкасы бик күптәннән бирле халык медицинасында кан туктату өчен кулланыла.* Ботаника. **Көтүче уены** — уенга катнашучылар ике рәт булып тезелеп, ә алар алдында торучы кеше парлап йөгереп киткән уйнаучыларның берсен тотудан гыйбарәт уен. **Көтүче энәсе** *бот.* — яран гөленә охшаган чүп үлән; торнабаш; *русчасы:* аистник.

КӨТҮЧЕЛЕК *и.* Көтүче хезмәте, көтүче булып эшләү. *Араларында, байтак кына хатын-кызлар белән бергә, элек вакытта гомер буена бурлаклыкта, --- көтүчелектә йөргән Чатан Шаһи, Кушавыз Гыймади шикелле авылның ярлылары, батраклары да бар.* М. Гали. *Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән.* Г. Кутуй.

КӨФЕР *и. иск. дини.* Ислам динендә: аллага ышанмау, алланы инкяр итү; гөнаһ эш. [*Мулла:*] *Уразада гошер бирмәү Зур гөнаһ бит, көфер бит.* М. Жәлил. || *с. мәгъ.* Аллага ышанмауны белдергән; гөнаһ булган; гөнаһлы. *Арада шундый бер мәзге бар: „Башларына мондый көфер сорау килүчеләрне салып суктыру өчен, алла, имештер, урманда чыбык кисеп яткан“.* Г. Гобәй.

◇ **Көфер печате сугу (басу)** — гөнаһлы дип табу, гөнаһлы дип санау. *Шул почмакка һәр көн Печән базары мещаннары жыелышып, һәр узган-барганга көфер печате сугып, һәртөрле хулиганлыклар эшләп калалар иде.* М. Гали. **Көфер почмагы** — 1) Октябрь революциясенә кадәр Казанда, Печән базары мәчете янында, кадимче карагруһ сәүдәгәрләрнең, динчеләрнең һәртөрле прогрессив күренешләрне, алдынгы кешеләрне сүгү, хурлау өчен бергә жыелып тора торган урынын халык шулай атаган. *Хөсәен, халык дәрьясын кичеп, көфер почмагына таба юл тотты.* А. Расих; 2) *күч.* нинди дә булса кичәдә, мәжлестә шунда килүчеләрне тикшереп-күзәтеп һәм тәнкыйтләп торучы кешеләр жыелган урын, гайбәт почмагы. *Һәрбер танцы залының үзенә күрә „көфер почмагы“ була. Анда башкаларны күзәтүдән тәм табучы --- кызлар жыела.* Ш. Хөсәенов. **Көфер сүз** — 1) *дини.* аллага каршы сүз, алланы мәскәрәләү сүзе, гөнаһ сүз. [*Хафиз:*] *Көфер сүз сөйлисең, Бибижиһан, тәкъдирдә язылганга ышанмыйсыңмы әллә син?* Ә. Фәйзи; 2) начар, эшәке сүз. *Кызның агасы артларыннан төрле көфер сүзләр илә ләгънәтләр укып калды.* Ш. Мөхәммәдев.

КӨФЕРЛЕК *и. иск. дини.* Аллага, дингә ышанмау. || *күч.* Биргән антыңа хыянәт итү, вәгъдәңдә тормау; начар эш; ярамаган эш. *Мич башына менмәм, дип [язганмын]; менмәссең, аркаң туңса! „Менмәмен мин, ходай кушса“, — дип, „ходай кушса“сын да язганмын лабаса. Бу нигә көферлегем житте икән! — дим дә кычкырып көләм.* Г. Тукай. — *Дөньяда шушындый жәһиллек тә, мөкатдәс саналган бөтен тойгыларны аяк астына таптап мыскыллый торган шушындый көферлек тә булуы мөмкинме?..* Ш. Маннур.

КӨФЕРЛӘНҮ *ф. иск. дини.* Алланы инкяр итү, аллага каршы сүз әйтү; берәр гөнаһлы эш эшләү.

КӨФРИЯТ *и. иск. дини. к.* көферлек. *Муллаларны „элеп алып, селкеп салуы“, аннан соң үзенең „көфрияты“, әллә нинди тарихлары-вакыйгалары белән дә тирә-якны шаулатуы --- Зыяны нинди дер каһарман сыман итеп күрсәтәләр иде.* Г. Ибраһимов.

КӨФҮ *и. иск.* Тиң кеше, тиңдәш; пар, иш. *„Мин шуның белән тиң вә аңа көфү микәнни“, дигән уйлар [Зәйнәпнең] күңеленнән кичте.* М. Гафури. || Тиң булу, пар булу. [*Шагыйрь*] *егет белән кыз арасында тигезлек, --- көфү турында да уйланып торуя.* Г. Нигъмәти.

КӨХӘЛ *и. иск.* Сөрмә. [*Әбүгалисина:*] *Сиңа мин бер чара күрсәтә алам. Күрәмсең бу тузан сөрмәсен? Көхәл дигән әйбер.* Н. Исәнбәт.

КӨЧ *и.* 1. Терек затларның нинди дә булса физик эш яки хәрәкәт башкарырга сәләтә; кешенең, хайванның физик энергиясе. *Газинур беләгендә таулар актарырлык көч сизде.* Г. Әпсәләмов. *Яңа атның көче сабанда күренә.* Мәкаль. || Кемнең яки нәрсәнең дә булса яшәү сәләте, яшәргә сәләте; яшәү инстинкты. *Без синең йөрәк утыңнан яшәү көче алабыз.* Ә. Еникәй. *Һәрбер колхоз, һәрбер гигант совхоз Яшәү көче безгә бирәчәк!* Һ. Такташ. || Нинди дә булса эш башкара торган физик энергия; хезмәт. *Сәгыйть байның төп идеясе дә Кәрим байныкы кебек үк, мал жыю, баю, кеше көчен эксплуатацияләү.* М. Гали.

2. Кешенең нинди дә булса эшне башкару өчен кирәк булган физик, акыл һәм рухи энергиясе; тырышлык. [*Әмиржан:*] *Без үткән көз һәм кыш көне бөтен көчебезне отряд туплау эшенә куйдык.* Ш. Камал. || Кешенең нинди дә булса эш башкарырга сәләте, осталыгы. *Бары тушь белән генә эшләнгән, китап бите күләменнән зур булмаган бу рәсемгә художник бөтен иҗат көчен, бөтен дәртен, сәлә-*

тен салган булса кирәк. А. Шамов. || Аерым төр кешеләр төркеменең (сыйныф, катлау һ. б. ның) сәләте, куәте. *Студия - - - үз составындагы артистларның көчен шул репертуарны үзләштерүгә тупларга һәм шулай итеп опера театрының ачылуын хәзерләргә тиеш иде.* М. Җәлил. *Коллектив көч җиңде.* Г. Гобәй.

3. Нәрсәнең дә булса эш-хәрәкәт башкару сәләте, энергиясе, егәрлеге. — *Радионың көче Мәскәү белән ике арада сөйләшергә җитәрлек түгел.* Щ. Усманов.

4. Куәт (дәүләтнең, армиянең һ. б.). *Данлыклы көрәш бара, - - - Социалистик хуҗалыкның Көчен үрчетү өчен.* Ә. Ерикәй. *Дошман каршы тора алмады Кызыл Армиянең көченә.* М. Гафури.

5. Нинди дә булса эшчәнлек яки эшнең, хәрәкәтнең һ. б. интенсивлыгы, аның чагылу дәрәҗәсе. *Халык күбәйгән саен, тавышның да көче арта барды.* Г. Ибраһимов. || Кешедәге рухи сыйфатларның (тәэсир, кичереш һ. б.) чагылу дәрәҗәсе, тирәнлеге, интенсивлыгы. — *Мин мондагы бер нәрсәне, ана мәхәббәтенең көчен аңлата алмыйм гына түгел, үзем дә аңламыйм — тик сизәм генә.* Ш. Камал.

6. Кешенең рухи эшчәнлеккә сәләте; рухи сәләт. [*Мирхәйдәр:*] *Көч дип мин беләк көчен генә әйтмим. Акыл көче дә — көч.* Ә. Фәйзи.

7. Нинди дә булса берәр эшчәнлекнең чыганагы; кемгә яки нәрсәгә дә булса йогынты ясаган, мәҗбүр иткән нәрсә. *Алар ягында революциянең барышын туктатырлык көч юк иде инде.* К. Нәҗми.

8. Нинди дә булса энергиянең чыганагы булган материаль башлангыч, материаль нәрсә. *Атом көче. Табигать көчләре.* □ *Җитештерүче көчләрне җәмгыятьнең һәм аның барлык гражданнарының ихтыяҗларын мул канәгатьләндерергә мөмкинлек бирерлек итеп үчәк аттыруны тәэмин итү өчен беренче чиратта түбәндәгеләрне тормышка ашырырга кирәк.* Соц. Тат. [*Хатын:*] *Син, улым, тартынып, бәрәңге генә ашап утырма. - - - Бәрәңгенең көче юк аның.* И. Гази.

9. *күч.* Гаскәр; хәрби часть, хәрби подразделение. *Орск гарнизонындагы ике меңнән артык гаскәр белән берләшкәндә, бу көч Орскины озак вакыт дошманнан саклый алачак.* Ш. Усманов.

10. *күч.* Нинди дә булса эш башкаручы кеше, аерым шәхес. *Бикташев колхозда ялгыз хәрәкәт итүче бер көч итебрәк бирелгән.* М. Җәлил. *Такташ үлү белән татар совет әдәбияты үсеп бара торган яшь бер көчне югалтты.* Г. Нигъмәти. || Нинди дә булса бер эш яки профессия белән шөгыльләнүче кешеләр. *Дошманның берничә ДОТын җимереп, барлык тере көчләрен кырганнар.* Т. Гыйззәт. *Ләкин сугыш вакытында, колхозда эшче көче җитмәгәндә, болай йөрү әйбәт була микән соң?* Г. Гобәй.

11. Нинди дә булса үзенчәлекләре яки эшчәнлек максатлары, юнәлешләре белән аерылып торган иҗтимагый төркем, җәмгыятьнең бер өлеше. *Шәһәрнең политик, сыйнфый көчләре башлыча ике үзәктә кайный иделәр.* Ш. Камал. *Бу җыелышта* [*Газинур*] *партиянең бер җан, бер тән белән сулавын, бергә тупланган куәтле, какшамас көч икәнен тагын да тирәнрәк аңлады.* Г. Әпсәләмов.

12. *махс.* Җисемне, материяне тынычлык хәленнән чыгаруга яки аларның тизлеген, юнәлешен үзгәртүгә сәбәп булучы энергия. *Үзәктән куучы көч.* □ *Бер әйбернең икенче әйбергә ничек тәэсир итүенә карап, көчләр эластиклык көче, авырлык көче, ышкылу көче, шулай ук электр һәм магнитка бәйле булган көчләр дип аталалар.* Физика.

13. *махс.* Хокукка ия булу, хокуклылык. *Карарның көче югалу. Законның үз көчендә калуы.* || Йогынты ясау сәләте, тәэсир итү сәләте. *Хәлимнең ышанычлы сүзләре* [*малайлар*] *алдында көчләрен җуйдылар.* Г. Гобәй.

14. *хәб. функ. сөйл.* Авыр, кыен; авыр булу, кыен булу. *Әнкә белән бала калса — анага көч; Ата белән калса — балага көч.* Мәкаль.

◇ **Көч(ен) бирү** — көч кулланып, көч чыгарып, көч белән. *Гариф, көймәдә бертуктамый көч бирү ишкәнгә күрә, кызган иде.* Ш. Камал. **Көч бирү** — 1) рухландыру, дәрт бирү, илһам бирү. *Эшчеләргә коммунистлар юл күрсәтә, көч бирә.* М. Җәлил. *Менә шул нәфрәт миңа сугышта көч бирә, кыюлык бирә.* А. Шамов; 2) куәтләү, дөреслеген раслау (сүзнең, фикернең һ. б.). **Көч керү** — 1) хәл керү, көч барлыкка килү; 2) нинди дә булса бер эш башкаруда, берәр нәрсә эшләүдә физик көч белән катнашу. [*Әптерәш:*] *Бу йортларга минем көчем, каным кергән, минем хакым бар.* Г. Ибраһимов. **Көч килү** — 1) чамадан тыш эшләү яки артык күп йөрү һ. б. ш. сәбәпләр аркасында организмга зарар килү, берәр әгъза авырту; өзлегү; 2) *күч.* авырга, кыенга туры килү. **Көч китерү** — чамадан тыш эшләү яки артык күп йөрү һ. б. ш. сәбәпләр аркасында берәр әгъзага зарар китерү, берәр әгъзаны авырттыру. [*Хөсәен:*] *Чамалап укыгыз, гыйлемне кирәгеннән артык алып, акылыгызга көч китерә күрмәгез.* Ә. Фәйзи. **Көч кую (салу)** — 1) көч сарыф итеп эшләү, физик энергия куллану. *Сәйфинең бу сүзләре әллә никадәр көч куеп тау башына мендереп җиткергән йөкне кире төртеп төшерү белән бер иде.* Г. Бәширов. *Бу иксез-чиксез басуларны эшкәртү өчен* [*кеше*] *нихәтле көч салган да нихәтле тир түккән.* Г. Әпсәләмов; 2) күңел биреп, бөтен сәләтне биреп эшләү. [*Сәйфулла*] *бик якын дустының — үзе белән бергә Колчакны Читага кадәр куып барган, авылда яңа тормыш өчен күп көч куйган - - - Шәрифулланың улы иде.* Ә. Еники. **Көч политикасы** — көч (гаскәр һ. б. ш.) кулланып үткәрелә торган политика. *Совет дәүләтенә карата көч политикасы куллану - - - уңышсызлыкка очрады.* КПСС тарихы. **Көч сынау (сынашу)** — нинди дә булса эштә сәләтне, көчне күрсәтү. *Шулай да* [*Әкбәрев*], *көтелмәгәндә көч сынарга туры килүенә шатланып, җырчының биленнән эләктереп тә алды.* А. Әхмәт. **Көч түгү** — көч чыгарып эшләү, тырышып эшләү. [*Хәйдәр:*] *Җәмгыятьтә үзеннән берни дә өстәмичә, үзе көч түкмичә, дегет чилгедәй тагылып кына бара икән, ул кеше безнең җәмгыятьнең чын мәгънәсендә кыйммәтле кешесе түгел!* Г. Бәширов. **Көч җиткәнчә, көч(е) җиткән кадәр, көч(е) җиткән хәтле** — мөмкин булган кадәр, мөмкин булганча. *Вакытсыз картайган, һәрвакыт ыңгырашып-сыкранып йөргән әтисен кызганган Газинур, көче җиткән кадәр, аңа булышырга тырыша.* Г. Әпсәләмов. **Көч җитү** — булдыра алу, эшли алу; хәленнән килү. [*Шәкерт*] *үзен кая куярга, нишләргә белмичә, йөрәгенә кабынган утны сүндерергә көче җитмәстән, арлы-бирле сугылды.* Г. Бәширов. **Көче тоту** — кара ышану буенча: кеше хезмәтен, көчен үзләштерүчегә зарар килү. **Көченнән (көчләреннән) килү** — булдыра алу, эшли алу; көч җитү. [*Бибиҗиһан:*] *Бик баерлар иде дә, адәм таларга көчләреннән килми, куркалар.* Ә. Фәйзи. **Көчтән калу** — көч бетү, физик яктан көчсезгә әйләнү. [*Хан:*] *Мин картайдым, - - - көчтән калдым.* Н. Исәнбәт. **Көчтән (көченнән) килгән кадәр, көчтән килгәнчә** — *к.* көч җиткәнчә. *Көчтән килгән кадәр тырышу.* **Көчтән (көченнән) килү** — булдыра алу. *Карт белән карчык - - - көчтән килгән хезмәтне кызганмыйлар.* Г. Тукай. **Көчтән (көченнән) таю** — хәлсезләнү, хәл бетү, көч бетү. [*Хәкимҗан абзый*] *аягы яраланган*

Сәйфулласын да - - - тәмам хәле беткәнче, көчтән таеп егылганчы, аксый-аксый һәм мылтыгыннан ата-ата барган итеп күз алдына китерә. А. Шамов. **Көчтән тыш** — булган мөмкинлекләрдән дә артык; бик тырышып, бик нык. *Көчтән тыш эшләү.*

КӨЧ-БӘЛА: көч-бәла белән — авырлык белән, көчкә. *Мостафа, карандаш башы белән өстәлне шакылдатып, көч-бәла белән тынлык урнаштырды.* Ш. Камал.

КӨЧ-ДӘРМАН *җыйг. и.* Көч, гайрәт, сәләт. *Бетсә дә көч-дәрманым, Рух, дәртләр әле сүнмәгән.* Б. Рәхмәт.

КӨЧ-ЕГӘР *җыйг. и. к.* көч-куәт. *Хак булса, Пугачев та тирә-яктагы татар, башкорт авылларыннан көч-егәр килгәләгәнче, чатырлар корып, шунда яткан.* М. Хәсәнов.

КӨЧЕК *и.* 1. Эт баласы. *Кинәттән бер капка астыннан кечкенә генә көчек тәф-тәф иткәч тә,- - - аның артыннан иллеләп этләр җыелып та алды.* Г. Тукай. *Алпавыт чыга да үз кулы белән хатын саен икешәр көчек бүлеп бирә.* Г. Гобәй.

2. *күч. гади с. кимс.* Балага яки яшь кешегә карата кимсетеп әйтү сүзе. [*Төрмә начальнигы:*] *Карагыз әле сез аны, нинди кечкенә көчектә* [*Илсөярдә*] *никадәр зур кирелек.* Г. Гобәй. || *тирг.* Хуҗасына турылыклы хезмәт итүче иярченнәргә карата яки тәҗрибәсез, булдыксыз дип саналган кеше турында әйтелә. [*Миңнулла:*] *Малик акларның көчекләрен минем өстемә җибәрә: мин инде хәзер өемдә дә кунмыйм.* И. Гази. [*Хан:*] *Мин өйрәтим әле ул көчекне* [*Җикмәргәнне*]. М. Җәлил.

КӨЧКӘ *рәв.* 1. Эш-хәрәкәтнең, күренешнең бик авырлык белән башкарылуын белдерә: көч-хәл белән, чак кына, чак-чак кына. [*Исмәгыйль*], *аягын көчкә тартып чыгара-чыгара, җәяүләп китте.* Г. Тукай. *Зур самолетны көчкә сыйдыра алган ике платформаның тәгәрмәчләре берьюлы тәгәри башладылар.* Г. Гобәй.

2. Эш-хәрәкәтнең тулы башкарылмавын белдерә. *Әллә нинди, караңгылы-яктылы бүлмәдә бик әкрен-бик көчкә генә сөйләшәләр, сүзләре аңлашылмый.* Ш. Камал.

КӨЧ-КУӘТ *җыйг. и. к.* көч (1, 2, 4 мәгъ.). [*Карт аучы:*] *Таулар, кешедә ихтыяр көчен үстергән кебек, кешедән көч-куәт тә сорый.* Г. Минский. *Тавыш бирдем халкым юлы Киңәя төшсен өчен, Илемнең көче-куәте Күбәя төшсен өчен.* Ә. Ерикәй.

КӨЧКӘ-КӨЧКӘ *рәв.* Мәгънәсе „көчкә“ сүзенә туры килә, ләкин экспрессив ягы тагын да көчлерәк. *Разия кып-кызыл кызарынды, мин көтмәгән кадәр каушады да, көчкә-көчкә генә миңа ишетелерлек тавыш белән: „Мин сездән оялам, Рәшат“, — диде.* Ф. Әмирхан.

КӨЧЛЕ *с.* 1. Физик көче зур булган, зур физик көчкә ия булган. *Хәлим, винтовкасына ияреп, бик тиз генә сикереп торды һәм бандитның аңа караганда бик күп көчле, таза икәнен шунда ук сизеп алды.* А. Шамов. [*Гыйният*], *яңадан көзге алдына барып, ике кулын бөгеп көчле мускулларын кабарта.* А. Әхмәт. *Җирән кашка яшь булса да көчле икән: шул чаклы печән белән биш кешене бертуктаусыз йөгертеп алып кайтты.* Г. Ибраһимов.

2. Ихтыяр көче зур, нык ихтыярлы; тәвәккәл, кыю; кыенлыкларны жиңеп чыга торган. *Һәрвакыт күтәренке күңелле, бертөрле авырлыкка да бирелми торган нык кеше, көчле кеше булып күренсә дә, сугыш вакытында район белән җитәкчелек итүнең кыенлыгын* [*Мансуров*] *үзе генә белә иде.* Г. Бәширов. *Большевиклар партиясе көчле кешеләр, тимер көрәшчеләр сорый.* Ш. Камал.

3. Эш-хәрәкәт башкару көче зур булган, зур физик энергиягә ия, егәрле (механизмнар, машиналар турында). *Тиз еллардан көчле тракторлар, Комбайннар белән басулар гөрләп торыр.* М. Гафури.

4. Үтәлү-башкарылу көче зур булган, көчлелеге белән аерылып торган. *Кар көрте астындагы тар амбразурадан яңадан көчле ут ыргылды.* Г. Әпсәләмов. *Язгы ташкын алай көчле булмаса да, ишек алларының яртысына су кергән иде инде.* Ф. Кәрим. *Пәрдә көчле музыка белән ачыла.* Ф. Бурнаш. || Чагылыш дәрәҗәсе зур булган; көче зур булган, интенсив. *Көчле реакция еллары башлангач та,* [*Г. Камал*] *буржуа һәм вак буржуа язучылары кебек өметсезлеккә бирелмәде.* М. Гали. *Ләкин* [*гаеплүче*], *һичкемгә карамастан, көчле яңгыравык тавыш белән дәвам итте.* Г. Ибраһимов. *Читкә утыртылган резедалар көчле исләре белән юл өстендәге һаваны аңкыталар.* Ф. Әмирхан. || Тирән, зур (хис, тәэсир һ. б. турында). *Көчле дәрт.* □ *Җырлыйм Зөбәйдәнең наборщикка Булган көчле гыйшкы турында.* һ. Такташ. *Йөрәк кайный тулып диңгез кадәр көчле теләкләрдән.* Н. Исәнбәт.

5. Куәтле, зур куәткә ия булган (дәүләт, коллектив һ. б.). *Көчле держава.* □ *Җиңелмәслек көчле безнең ил.* М. Җәлил. *Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, шагыйрь ул.* Г. Тукай. || Ныгытылган һәм яхшы коралландырылган. *Аннары бу участокта немецларның оборонасы да бик көчле.* И. Гази. || Сугышу көче зур булган, нык коралланган. [*Варламов:*] *Кызылларның көчле кавалериясе атакага ташлана.* Т. Гыйззәт.

6. Тәэсир көче зур, нык тәэсир итә торган, тәэсирле. [*Ул*] *һичбер нинди ялынудан йомшамаучы дәвәргә бер-бер артлы көчле сүзләр әйтергә омтылды.* К. Нәҗми. *Тукай фольклорны феодаль крепостнойлык калдыкларына каршы көрәштә көчле коралларның берсе итеп алды.* Г. Нигъмәти. || Нык йогынты ясый торган, нәтиҗә бирә торган. *Совет иленде көчле тәнкыйть — һичбер сынмый торган корыч ул.* М. Гафури.

7. Нигезле, ышандыргыч, исбатлау көче зур. *Минем дәлилләрем көчле һәм ышандыргыч иде.* А. Шамов.

8. Кемгә яки нәрсәгә дә булса нәтиҗәле йогынты ясый торган, тиз дәвалый торган (дарулар турында). *Көчле булды дару, егет күңеле Ике чирдән бергә котылды.* М. Җәлил. || Нык тәэсир итә торган, куәтле. *Көчле серкә.* □ *Көннәр суык, - - -* [*өшүчеләр*] *Бик нык суга гөнаһы юк бутылкага, диеп аңар: „Эчеңдәге суны чыгар, аның белән безне җылыт, безне сугар, көчле хәмер! Синең кулда зур ихтыяр“.* Г. Тукай.

9. *сөйл.* Сәләтле, талантлы, оста. *„Хаҗи әфәнде өйләнә“ һәм „Сәмруг кош“ кебек әсәрләрендә инде без* [*Ш. Камалны*] *гаҗәп көчле һәм үткен бер сатирик итеп күрәбез.* М. Җәлил. || Күп белүче, мәгълүматы зур; сәләтле, булдыра алучы. *Көчле укучы.*

◇ **Көчленеке замана** — кем көчле, шул яхшы яши торган чор, көчкә таянып эш итүчеләр өчен генә яхшы вакыт дигән мәгънәне белдерә (сыйнфый жәмгыять турында). [*Галиулла*], *алпавыт талап алган Ышна җирен кире кайтарып булмасмы, дип сөйләнә башлаганга да ике ел үтеп китте инде. - - - Һаман шул: көчленеке замана.* И. Гази. **Көчле як** — кемнең яки нәрсәнең дә булса бик кыйммәтле, әһәмиятле үзенчәлеге, кыйммәтле сыйфаты. [*Бу кыланышлар*] *кызлар* [*табигатенең*] *иң матур, иң көчле яклары булып киттеләр.* Ф. Әмирхан.

КӨЧЛЕК *и. кит. сир.* Мәжбүр итү, көчләү, ирексезләү. [*Фәхри:*] *Әмма бергүгә дә көчлек юк — телә-*

гән керә, теләмәгән юк, шулай да мин ышанам: бер көн килер, кулак булмаган крестьяннар һәммәсе дә артельгә керерләр. Г. Ибраһимов.

◇ **Көчлек белән** — 1) зур көч куеп, көч кулланып. *Кайнап торган шәһәр уртасыннан Әкрен генә бара бер кеше, ←--- Аркасына аскан зур капчыгын Көчлек белән чак-чак кына күтәрә.* М. Гафури; 2) тырышып, үз-үзеңне мәжбүр итеп. [*Хезмәтче хатын*] *киткәч тә, бик көчлек белән урынымнан торып, чишенә башладым.* Ш. Камал. **Көчлек килү** — *к.* көч килү. *Әгәр дә шул чукрак хәлемдә бер русның җырлап утырган хәленә карасам, мин аның авызының ертылганчы ачылуыннан вә үзенә көчлек килүеннән,* [*шиксез*] *бу җырлый, дип уйлар идем.* Г. Тукай.

КӨЧЛЕЛЕК *и.* **1.** Зур физик көчкә ия булу, көчле булу. [*Хәлимнең*] *сылу, төз һәм шуның белән бергә көчлелекне, ныклыкны да күрсәтеп торган буен күреп алган кайбер хатын-кызлар, узып киткәч, туктап, аның артыннан карап калалар иде.* А. Шамов.

2. Куәтле булу, зур куәткә ия булу. *Чөнки шушы армиянең бүгенге, иртәнге көчлелеге, ныклыгы гына безгә солых бирә ала.* Ф. Әмирхан.

3. Эш-хәрәкәтнең, кичерешләрнең чагылыш дәрәҗәсе зур булу, чагылышы көчле булу. *Без сагынуның чиксезлегенә, мәхәббәтнең көчлелегенә, җылы хисләрнең тирәнлегенә хәйран калдык.* А. Шамов. || Чирнең көчле булуы, авырлыгы турында. *Кайсы чирнең миндә көчлелеген Доктор үзе сизә торгандыр.* М. Җәлил.

КӨЧЛӘНҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* көчләү.

2. *сөйл.* Тырышу, бөтен көчне бирү; көчәнү. *Карт һаман да китте алга, хәлсез атламый көчләнеп.* Н. Исәнбәт. *Мин торырга, күземне ачарга көчләнәм.* Ш. Әхмәдиев. || Теләмәсә дә үзен мәжбүр итү, ясалма тырышу. *Хәят уйчан гына елмайды һәм, көчләнеп, җиңелчә вә нечкә генә итеп тамак кырды.* Ф. Әмирхан. *Ире аны яратмыйча, тешен кысып, көчләнеп торырга мәжбүр булган.* Ә. Еники.

3. *рәв. мәгъ.* **көчләнеп.** Ирексезләп, мәжбүри рәвештә, көчләп. *Сания апамның көчләнеп кияүгә бирелүен --- әнинең әрнеп сөйләүләреннән белдем.* М. Гафури. [*Хәсән:*] *Менә бу солдатларның күбесе— алданып, кайберләре аклар тарафыннан көчләнеп алынган туганнарыбыз.* Һ. Такташ.

КӨЧЛӘҮ *ф.* **1.** Кемне дә булса берәр нәрсә эшләргә мәжбүр итү, ирексезләү; ирексезләп кушу. [*Галиулла:*] *Туктале син, Николай Кузьмич, күңел бер дә тартмый бит анда, көчләмә инде син...* И. Гази. || *сөйл.* Кыстау, үтенеп сорау. [*Галимә апа*] *бүген --- чәйне дә бер генә чынаяк, әни көчләгәнгә, мәжбүри рәвештәрәк эчкән кебек кенә эчте.* М. Гафури.

2. Көч кулланып җенси мөнәсәбәткә керергә мәжбүр итү. [*Аклар*] *Конские Раздорыда ике кыз укытучыны көчләгәннән соң буып үтергәннәр.* А. Шамов.

3. *рәв. мәгъ.* **көчләп.** Көч белән, көч кулланып; тыгызлап. *Буш түгел букча,* [*шәкертләр*] *китергәннәр аны көчләп төяп.* Г. Тукай.

КӨЧСЕЗ *с.* **1.** Физик көче булмаган яки бик аз булган, хәлсез. *Бер кеше бар: үзе бетерешкән, көчсез, чалгы да күтәрә алмый, ләкин итекне бик матур тегә.* Г. Тукай. [*Сәрби:*] *Актык чиккә җиткәндә, мин шушы көчсез кулларым белән я үземне, я сине харап итә алырмын әле.* Ф. Бурнаш.

2. Берәр эш башкарырга мөмкинлеге яки сәләте булмаган; сәләтсез. *Болар арасында башта изелгән, өметсезлеккә бирелгән, көчсез, ә соңыннан сөйгәне һәм халык өчен үзен корбан итүгә барып җиткән патриотка батыр Рәйханә образы үзәк урынны ала.* М. Җәлил. *Әллә ниләр башкарыр кебек йөргән иде* [*Галиулла*], *көчсез дә, булдыксыз да түгел иде кебек.* И. Гази. | *и. мәгъ. Марат бу сугуның көчлеләрнең көчсезләрне җәберләү, кимсетү икәнен инстинкт буенча аңлады.* Г. Гобәй.

3. Көче, чагылыш дәрәҗәсе зур булмаган (беленер-беленмәс, ишетелер-ишетелмәс һ. б.). *Аның --- көчсез тавышы ишетелә.* А. Әхмәт.

КӨЧСЕЗЛЕК *и.* **1.** Физик көч булмау яки бик аз булу, көч җитмәү; хәлсезлек. [*Рахиль:*] *Менә шунда инде мин үземнең көчсезлегемне, зәгыйфьлегемне бик ачык сизәм.* А. Шамов.

2. Берәр эш башкарырга мөмкинлек яки сәләт булмау; сәләтсезлек. *Бу нәрсә җәдитчеләрнең һәм либераль буржуаның көчсезлеген, башлаган эшен ахырга кадәр алып барып чыгара алмаганлыгын күрсәтә.* М. Гали. — *Үземдәге наданлыкны, тәҗрибәсезлекне, көчсезлекне сизү шундый авыр булды.* М. Әмир.

КӨЧСЕЗЛӘНДЕРҮ *ф.* Көчсез итү, көчсезгә әйләндерү. *Австро-герман армияләренең барлык төп ударларын рус армиясенең үз өстенә алуы австро-германнарны көчсезләндерә.* Яңа тарих. *Нинаять, иртә балыган таң, ачылганнан-ачыла барып, өй эчендәге ут яктысын бөтенләй көчсезләндергәч, Гөлниса кунагына урын җәйде.* Г. Минский.

КӨЧСЕЗЛӘНҮ *ф.* **1.** Көчне югалту, көчсезгә әйләнү, көчсез булып калу. *Авырудан соң көчсезләнеп калган, гади вакытта исерткеч* [*эчми*] *торган Шакиргә бу өч рюмка гаҗәеп тиз тәэсир итте.* Ф. Әмирхан. *Кодрәтле, киң җилкәле, имәндәй таза кеше, көчсезләнеп, Илсөярнең аяк астына егылды.* Г. Гобәй.

2. Куәте бетү, куәте кимү (дәүләт, җәмгыять һ. б. ш. турында). *Империалистик сугышлар империалистларның үзара көчсезләнүен китереп чыгаралар.* Яңа тарих.

КӨЧСЕЗӘЮ *ф. сөйл. к.* көчсезләнү. *Аның бу шатлыгы алдында теге шомлы хәбәрдән --- туган кайгы-хафасы кечерәеп, көчсезәеп калды.* Г. Минский.

КӨЧ-ХӘЛ *җый. и.* Егәр, хәл. *Көч-хәл алу.* □ *Алар тагын байтак кына урдылар да чәйләп алдылар. Янә арган куллар язылып, көч-хәл кереп киткәндәй булды.* Ак юл.

◇ **Көч-хәл белән** — 1) көч куеп, бик тырышып; авырлык белән. *Сәгъди абзый белән Зөһрә апа килеп таза гәүдәле Сабираны тотып алдылар һәм көч-хәл белән аны кире сәкегә китереп яткырдылар.* Ә. Фәйзи; 2) көчкә, көчкә-көчкә генә, чак-чак кына. *Моңарчы күз яшьләрен көч-хәл белән тыеп тоткан карчык кинәт әкрен генә пыскылдап елап җибәрде.* А. Шамов. *Шуннан соң Җамали, башына акылын җыеп, көч-хәл белән генә тынычланып, үзенең әлекке хәленә килде.* М. Гали.

КӨЧ-ЯРДӘМ *җый. и.* Ярдәм, булышлык. [*Егет:*] *Мин дә көч-ярдәм бирермен, әйдә, иптәш, кузгалыйк, Шул агачны бергә-бергә ушбу арбага салыйк.* Г. Тукай.

КӨЧӘЙТКЕЧ I *и. тех.* Токның көчәнешен арттыра торган җайланма. *Ике каналлы көчәйткеч. Магнитлы көчәйткеч.*

Көчәйткеч лампа *тех.* — югары яки түбән ешлыктагы тирбәнешләрне көчәйтү өчен кулланыла торган электрон лампа.

КӨЧӘЙТКЕЧ II: **көчәйткеч кисәкчә** *лингв.* — үзләре ялганып килгән сүзгә көчәйтү төсмере бирә торган кисәкчә. *Сыйфатлар һәм рәвешләр алдында килә торган --- көчәйткеч кисәкчәләр сызыкча аркылы язылалар.* Тат. теле грамм.

КӨЧӘЙТҮ *ф.* **1.** Кемнең яки нәрсәнең дә булса көчен, куәтен арттыру, көчлерәк итү. *Бу хәл оборонада торучы дошманның позициясен, әлбәттә,*

көчәйтә, ә һөҗүм итүчеләр өчен өстәмә кыенлыклар тудыра. И. Гази.

2. Нинди дә булса эш-хәрәкәтнең үтәлү-башкарылу көчен арттыру. *Атлар ераклашкан саен, Караборын үзенең шыңшуын көчәйтте.* Һ. Такташ. *Алар талашны көчәйтә бирделәр.* Г. Ибраһимов. || Нинди дә булса үзенчәлек, сыйфат һ. б. шундыйларның чагылыш дәрәҗәсен (көчен) арттыру. *Җидееллык мәктәп аның бу сокланууын, бу эзләнү дәртен көчәйтте.* Г. Бәширов. *Дошманга бирмә юл бер дә, Уяулыкны көчәйт һәр җирдә.* Ә. Исхак.

3. Берәр төрле хәрби подразделениенең, группаның һ. б., составын һәм коралын ишәйтү юлы белән, сугышка хәзерлеген, сәләтен арттыру. *Караулны көчәйтү. Дозорны көчәйтү.* □ [*Хөсәен:*] *Утардагы сакчыларны көчәйтегез! Калган көчләрегезнең һәммәсен урманга.* Ф. Бурнаш.

Көчәйтү кисәкчәсе *линг.* — *к.* көчәйткеч кисәкчә. *Шуңа күрә мәктәп дәреслекләрендә* [*бу кисәкчәләрне*] *„көчәйтү кисәкчәләре“ дип исемләгәннәр.* В. Хангилдин.

КӨЧӘЛӘ *и. диал. к.* көҗәлә.

КӨЧӘНЕШ *и. физ.* Электр корылмасы хәрәкәт иткән вакытта электр энергиясенең көчен билгели торган зурлык. *Ток көчәнеше.* □ *Электр чылбырының билгеле бер бүлемтегендәге ток зурлыгы шул бүлемтектәге көчәнешкә туры пропорциональ, аның каршылыгына кире пропорциональ.* Физика.

КӨЧӘНЕШЛЕЛЕК *и. физ. тех.* Җисем корылмаларының тыгызлыгына пропорциональ булган электромагнит кырының характеристикасы.

КӨЧӘНҮ *ф. сөйл.* **1.** Мускулларны киеренке хәлгә китереп, бөтен көчкә нинди дә булса эш башкару яисә эш башкарырга тырышу. [*Көрәшчеләр*] *кызарынып, көчәнеп тартышырга, түгәрәк мәйданчык уртасында таптанырга тотындылар.* Н. Фәттах. [*Хатын:*] *Менә бервакыт баланың күзләре миңа төште, --- көчәнә-көчәнә анасының кулыннан ычкынырга тели.* Г. Минский.

2. Тырышу, азаплану. *Минемчә, ария һәм ансамбль булмаган урыннарда (бигрәк тә речитативта) урынсызга көчәнү, рифмалар төзеп маташу кирәкми.* М. Җәлил. *Рәхилә баскан урыныннан кузгалырга курка, ул үз хәлен аңларга көчәнә, каядыр югалган уйлау куәтен табарга тырыша.* Ә. Еники.

3. Теләмәсә дә үзен мәҗбүр итү; ясалма тырышу. *Сандецкий, бу сүзләрнең мәгънәсе турында баш ватарга иренеп, ирония аралаш көчәнеп елмайды.* К. Нәҗми.

КӨЧӘЮ *ф.* **1.** Көче арту, көч алу, көчлегә әйләнү. *Көчәйде Совет иле, Яшәрде Совет җире. Бушка түкмәдек канны без Егерменче елларда.* Ә. Ерикәй. *Бикмөхәммәдевләр фирмасы элек-электән районның бөтен сырье базарына хөкем йөртә торган булып, сугыш елларында бигрәк тә көчәеп китте.* Ш. Камал.

2. Эш-хәрәкәтнең үтәлүе-башкарылуы интенсивлашу; эш-хәрәкәт, процесс көчлегә әйләнеп китү. *Эшчеләр хәрәкәте шулкадәр көчәя ки, патша хөкүмәте социал-демократ большевикларның легаль органы „Правда“ газетасын чыгарырга рөхсәт бирергә мәҗбүр була.* Г. Нигъмәти. *Газинурның бу сүзләреннән соң алкышлар тагын да көчәйде һәм бик озак дәвам итте.* Г. Әпсәләмов. || Табигать күренешләренең көче арту, чагылыш дәрәҗәсе көчәю. *Җил көчәйгән саен, дулкын арта.* Ф. Кәрим. *Алар поезддан төшкәндә сибәлән кенә ява башлаган яңгыр, тора-бара көчәеп, чиләкләп коя башлады.* М. Гали. || Нинди дә булса үзлекнең, сыйфатның һ. б. билгеләрнең чагылыш дәрәҗәсе көчәю, интенсивлыгы арту. [*Хәятның*] *йөздәге кызыллык, колакларындагы яну тагы да көчәя иде.* Ф. Әмирхан. *Минем авыру Петербургта гаять тә көчәйде.* Г. Тукай.

3. Берәр төрле хәрби подразделение яки группаның, составы һәм коралы күбәю сәбәпле, сугышка сәләте, хәзерлеге арту.

КӨШ, КӨШ-КӨШ, КӨШ-Ш *ы.* Кошларны, кош-кортны куганда әйтелә. *Каравылчы Мифтахетдин --- казларны куа башлый: „Кө-өш! Көш, каһәрләр“.* А. Гыйләҗев. *Көш-көш, тилгән! Оч тизрәк моннан.* М. Җәлил. [*Бәдри — тавыкларга:*] *Көш-ш! Көненә ничә тапкыр ашатасың, аның өстенә караклыкка ябышалар, көш-ш!* М. Фәйзи. || *күч. сөйл.* Кешеләрне берәр җирдән куганда „китегез“ мәгънәсендә кулланыла.

КӨШЕГЕЗ *ы. к.* көш. [*Миңнулла — малайларга:*] *Көшегез, көш, мур кыргырлары, атка авыр итәсез!* И. Гази.

КӨШ-ШҮ, КӨШӘ *ы. к.* көш. [*Айтуган — тавыкка:*] *Көш-шү, каһәр суккыры! Көш-шү!* Г. Бәширов. *Без, әче тавыш белән, көш-шү дип кычкырып куя идек. Безнең тирәдә йөргән тилгәннәр очып китеп югалалар иде.* Ак юл. [*Карт*], *„Көшә!“ — дип, кош-тавыкларны куа.* Н. Думави.

КӨШЕЛ *и.* Ындырда сугылган ашлык өеме, сугылган ашлыктан ясалган өем. *Көшелгә арышны өеп бетердек тә, ындыр табагы кырыена утырып, җыйнаулап тәмәке тарта башладык.* М. Гали.

Көшел иләге — ашлык иләү өчен зур иләк.

КӨШКЕЛЛӘНҮ *ф. диал.* Назлану, кылану. *Тимери --- арка-җилкә сызлавы, тыны кысылуы турында зарлангалый башлады. Монда арка-җилкә сызлавыннан бигрәк, бераз картлык иркәлеге дә, бала-чага үстерүнең рәхәтен күреп калырга телән, бераз көшкеллә дә бар иде.* Г. Бәширов.

КӨЮ I *ф.* **1.** Кырые, тышкы ягы яну; янудан читчитләре күмергә әйләнү. *Көйгән икмәк күңелдән китмәс.* Мәкаль. *Расходның әлек чамалаганнан артыграк чыгуы, алма ләвәшләренең кирәгеннән артык кызып, берсенең кырые көеп китү, яшьләрнең бу эшкә илтифат итмичә уйнап-көлеп йөрүләре — һәммәсе аны борчый.* Ш. Камал.

2. Шиңү, шиңеп кору (үсемлекләр турында). *Үләннәр көю.* □ *Менә ул чирәме көеп беткән тузанлы җиргә көрәк очы белән сызгалый башлады.* И. Гази.

3. Кызу, эссегә әйләнү. *Көнозын кояш астында көеп яткан түбә калае күңелле шыбырдый иде.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Бик нык эчәсе килү, эсседән бик нык әлсерәү; эсселәнү. *Сусаудан көю.*

КӨЮ II *ф.* Кайгыру, көенү, хәсрәтләнү. [*Гали*] *һаман Зөләйха өчен көеп, хәсрәтләнеп яши бирә.* Г. Нигъмәти. *Минем иркәм, минем нечкәм Кайгырмасын, көймәсен.* Ә. Ерикәй. || Борчылу, кайгырту. — *Көям бирмәк өчен хөрлек, азатлыклар хатыннарга.* Г. Тукай. *Гатаның уйлары бик озак сугыштылар: „Син табигать сөюче, файдалы кошларның тормышлары өчен көюче, --- ни эшлисең син?“ — диделәр.* А. Алиш.

КӨЯ I *и.* Тәңкәканатлылар отрядыннан корты йон әйберләрне, ашлык бөртекләрен һәм үсемлекләрне зарарлый торган кечкенә күбәләк. *Ашлык көясе. Кием көясе.* □ [*Миңлебикә*], *көя ашап бетергән шәленең бер почмагын бөтәрли-бөтәрли, үзе белән бергә алып барган тылмач шәкерт аркылы шундагы адвокатларның берсенә үтенечен сөйләп бирде.* К. Нәҗми. || *күч.* Берәр төрле кайгы-борчу хисе турында. *Йөрәктә соңыннан озак еллар буе мине газаплаячак бер сәер ачыну көясе кузгалганын сизеп, башым иелә.* Ә. Баян.

КӨЯ II *и.* Бал кортлары кереп-чыгып йөрү өчен умарта тишеге.

КӨЯЗ *с.* 1. Киенү-ясануга, бизәнү-чибәрләнүгә бик нык игътибар бирүче, купшы яки киенгән-ясанган, бизәнгән-чибәрләнгән. *Гайрәтләнеп, көяз башкисәр Каты ябып керде ишекне.* М. Җәлил. | *и. мәгъ. Көязнең кулы җитмәс, Назлының әше бетмәс.* Әйтем. *Көяз туңмас, калтырар.* Әйтем. || *рәв. мәгъ.* Купшы итеп, матур итеп. *Көндезләрдә бик көяз киенгән биш-ун егетнең ава-түнә урам буйлап йөргәннәре, --- төннәрдә гармоньга кушылып моңланулар --- күңелгә бер дәрт, бер тәэсир бирәләр.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл.* Чибәр, матур, сылу. [*Миңлегали:*] *Аргамак, көяз кызлар төсле, кызыл билле прәннек кимергән кебек, шыгыр-шыгыр печән кимереп ята.* К. Тинчурин. *Күпреп торган көяз ак каеннар, Дулкынланып үскән тарылар Артыбызда көлеп калдылар.* М. Җәлил. || *рәв. мәгъ.* Матур, килешле. [*Галиулла:*] *Син алма әрҗәләре өстенә кукыраеп кына утырырсың да, дилбегәне көяз генә тотып, шәһәргә чыгып китәрсең.* И. Гази. *Соры песи, баскан саен аякларындагы пычракны селки-селки, көяз атлап, --- читән коймасы астына кереп югалды.* Г. Гобәй.

Көяз сандугач — башка кошлар тавышына охшатып тавыш чыгара алган, зур булмаган сайрар кош. **Көяз тургай** — *к.* купшыл.

КӨЯЗЛЕК *и.* 1. Көяз булу, купшылык. *Хәтта Варшау комендантында Булмагандыр мондый көязлек.* Н. Исәнбәт.

2. Көяз кыланыш, матур кыланыш. [*Хан*] *шунда ук Алтынчәчкә табан әйләнеп, аерым бер масаю һәм көязлек белән муенсаны, җәүһәрне аңа тәкъдим итә.* М. Җәлил.

Көязлек күрсәтү — көязләнү. *Боларның никрутлары көязлек күрсәтми: авылында, гади вакытта ничек булса, монда да шулай.* Г. Ибраһимов.

КӨЯЗЛӘНҮ *ф.* 1. Киенү-ясану, бизәнү-чибәрләнү. [*Бәдри:*] *Галиябану суга-нигә төшкәндә киенебрәк, көязләнебрәк төшсен иде.* М. Фәйзи.

2. Назлану, кылану. *Газинурның көязләнергә һәм бигрәк тә олы командирлар алдында „тәти" булып кыланырга яратмавын белгән солдат та көлүдән туктады.* Г. Әпсәләмов. [*Миңлегали:*] *Аргамак --- сылу кызлар төсле көязләнеп пошкырып куя.* К. Тинчурин.

КӨЯЛЕК: көялек килү — берәр яхшы эшнең киресе булу, киресе килеп чыгу. *Сукранма, Бәшир абзый, көялеге килер. Өлешеңә чыккан көмешең.* Г. Бәширов.

КӨЯЛӘК *с. диал.* Юкка борчылучан, тынгысыз. *Көяләк кеше.*

◇ **Көяләк җан** — борчылучан, тиз кайгыручан, тынычсыз кеше турында. *Көялә̆к җан! Җаның бер төшкә дә Беркетеп ул әллә нәрсә торалмый.* Х. Камалов.

КӨЯЛӘНҮ *ф. сөйл.* Тынычсызлану, борчылу. *Бу фактлар Шәмсегаянның --- юк-барга көяләнми торган, кыенлыкларны сабыр җиңә баручы хатын булуын күрсәтә.* Ф. Хатыйпов. *Гәрәй --- тәртипсезлек өчен көяләнеп карап бара икән.* А. Гыйләҗев.

КӨЯЛӘНҮЧӘН *с. сөйл.* Борчылучан, борчылу хисенә тиз бирелүчән. *Болай да көяләнүчән Тәхәү көне буе тынычсыз йөрде.* Г. Галиев.

КӨЯЛӘҮ I *ф. сөйл.* Көя төшү, көяләр барлыкка килү (берәр әйбердә).

КӨЯЛӘҮ II *ф. диал.* Бурсу, күгәрүдән исләнү. *Хуҗа хатын өелеп куелган көлтәләр янына килеп, бер башакны учына салып уды да иснәп карады: „Надя, кара әле, әллә көяли башлаган?"* Н. Дәүли.

КӨЯНТӘ *и.* 1. Чиләк, кәрзин кебек нәрсәләрне асып йөртү өчен очларында уентыгы яки тимер ыргаклары булган, җилкәгә салына торган озын иңсәле, махсус бөгеп ясалган агач җайланма. *Сания матур суга бара, Көянтәсе алмалы.* Җыр. *Юеш кер авыр булырга кирәк, кызның нәзек кенә буе көянтә астында сыгыла төшкән.* Ә. Фәйзи. || Көянтәгә эленгән чиләкләргә сыйган кадәр. *Бүген Иделнең текә ярыннан [Гайшә] унбер көянтә су мендереп, җимешләргә сипте, әллә ничаклы түтәлләр йомшартты.* Г. Ибраһимов.

2. *махс.* Көчләрнең тәэсир итү ноктасыннан ике якка аерылган рычаг (механизмнарда, үлчәүдә һ. б. кулланыла). *Менә өрлеккә асылынган үлчәү көянтәсе әле бер якка, әле икенче якка атынгалап торды да тынып калды.* Г. Бәширов.

Көянтә йолдыз(ы) — зодиакка кергән 12 йолдызлыкның берсе, йолдызларның урнашуы ягыннан көянтәне хәтерләтә; *русчасы:* весы. *Күп тә тормады, Тимер казык йолдызы белән Көянтә йолдызы да калыкты.* М. Гали.

КӨЯНТӘЛЕ: көянтәле үлчәү — тиң иңсәле рычагка нигезләнеп ясалган үлчәү. *Әйберләрнең авырлыгын ике төрле юл белән: 1) пружиналы һәм 2) көянтәле үлчәү ярдәмендә үлчәп була.* Физика.

◇ **Көянтәдәй бөгелү** — *к.* көянтә шикелле (кебек) бөгелү (бөкрәю, сыгылу һ. б.). *Эшли торгач шунда — җир астында, [эшчеләр] көянтәдәй бөгелеп төшкәннәр.* М. Гафури. **Көянтә йоткан** — иелеп-бөгелеп эшләргә яратмый, карап тору яки тик йөрүне артык күрә торган кеше турында. **Көянтә шикелле (кебек) бөгелү (бөкрәю, сыгылу** һ. б.) — гәүдә, буй үзенең турылыгын югалтканда, бөкрәйгән вакытта әйтелә. [*Хәмидә:*] *Аның селте көянтәсе шикелле сыгылып төшкән кызына җефәк шикелле улымны әрәм итәмме соң мин?* Г. Камал. *Көянтә шикелле урталай бөкрәйгән татар шәкерте узып китте.* Ф. Әмирхан.

КӨЯНТӘЛӘП *рәв.* Көянтә белән, көянтәгә асып (чиләкне һ. б.). *Көянтәләп су ташу.*

КӨЯНТӘЛӘҮ *ф.* Көянтәгә әлү, көянтәгә алу. *Көянтәләп пар чиләген, Суга бара чибәрем.* Ф. Бурнаш.

КӨЯНТӘ-ЧИЛӘК *җый. и.* Көянтә һәм чиләкләр (су китерү җиһазлары). [*Гөлбану*], *калын шәлен ябынып, көянтә-чиләген күтәреп, күрше җиңгәсе Мәфтухага керде.* Г. Ибраһимов.

КӨЯНӘК *с. диал. к.* көялә̆к. — *Шулкадәр көянәк, шулкадәрле тынгысыз җан булса да булыр икән.* М. Хәсәнов.

КӨҖЕ *и. этн. к.* күҗә.

КӨҖӘЛӘ *и. махс.* Орлыгыннан стрихнин алына торган, артык зур булмаган тропик агач, куак; *русчасы:* чилибуха.

КӨҢ *и. иск.* Кол кәнизәк, кол хатын. *Кызны асрый алмаган көң итәр, Улны асрый алмаган кол итәр.* Әйтем. | *с. мәгъ. Кол кияүгә көң җиңгә.* Әйтем.

КӨҢГЕР-КАҢГЫР *рәв. диал.* Бер көе, әкренләп (яшәү, тору).

КҮБАВЫЗ *и. зоол.* Имүчеләр классыннан паразит суалчан; *русчасы:* многоуст.

КҮБАРАЛЫКЛЫ *с. махс.* Берничә яки күп терәккә утыртылган (корылма, күпер һ. б.). *Күбаралыклы күпер. Күбаралыклы өрлек.*

КҮБАЯК *и. зоол.* Буынтыгаяклылар классыннан гәүдәсе суалчанга охшаган, күп аяклы бөҗәк; карышлавык; *русчасы:* многоножка.

КҮБЕ *и. сөйл. к.* күбесе. *Чакырылган кешеләрнең күбе килмәгән.* Г. Ибраһимов. *Безнең адреска булган бүгенге мактау „сүзләрен" безнең күбебез хәзергә кадәр бирәүдән дә ишеткәне юк иде.* М. Гали.

КҮБЕК I *и.* 1. Су болганып акканда яисә җил тәэсирендә дулкын өстендә барлыкка килгән үтә күренми торган куыклы-куыклы җиңел масса. *Хәлим*

тоныk су өстенә — берсен берсе куып аккан күбекләргә карап тора һәм сестра белән икәү бергә ераkта, кеше күзеннән бер читтә утыруына шатлана. А. Шамов. || Нинди дә булса сыекчаны болгатканда, селкеткәндә, кайнатканда һ. б. ш. очракларда аның өстендә барлыкка килгән үтә күренми торган куыклы җиңел масса. *Хуш, Минзәлә, синдә кунаk булдым үтеп барышлый. --- Шулай булгач, ничек язмый түзим Ак күбекле сыраң турында.* М. Җәлил. *Углекислый газ сыеклык белән берлектә күбек агынтысы барлыкка китерә.* Химия.

2. Куыклы массага әйләнгән сабын эремәсе. *Иске сабын үзенең ак йомшак күбекләре белән Солтанның битләрен, муеннарын, шалкан чәчләрлек булып каткан колак эчләрен иркәләп юа.* Г. Ибраһимов.

3. Бик нык ачуланганда, кайбер авырулар вакытында кешенең авызыннан чыга торган куыклы селәгәй, төкерек. *Аның кара чәчләре чәбәләнгән, күзләренең матур яктылыгы бетеп, тоныk кургашын төсенә кергән, күгәргән иреннәре ак күбек бөркегән хәлдә, тешләрен шыкырдатып ята иде.* Ш. Камал. *Уйнап торган кызлар һәм егетләрне күргәч, мулла, кызарынып-бүртенеп, авызыннан күбекләр чәчеп, сүзен әйтә алмый, алар өстенә ташланды.* М. Гали.

4. Авыр йөк тартудан, күп яки тиз йөрүдән кызган атта барлыкка килгән куыклы-куыклы ак тир. [*Гали абзый*] *атны кызулатканнан-кызулатты һәм бары тик шлея каешлары астында ак күбекләр күренә башлагач кына юыртудан туктатты.* Г. Әпсәләмов.

Күбек таш — полировкалау, шлифовкалау өчен кулланыла торган куыклы-куыклы, болыт сыман вулканик тау тоkымы; *к.* пемза. **Күбеккә бату** — тирләп күбек чыгу, күбек белән каплану (ат турында). *Аты күбеккә баткан ординарец килеп хәбәр бирде.* Ш. Усманов.

КҮБЕК II *и.* Күпертелгән йомырка агына шикәр оны кушып пешерелгән ашамлык. *Пешеп җиткән күбекләрне тактага тезеп суыткач, вазаларга салып табынга куела.* Хал. ашлары. [*Гөлбану:*] *Рәхәтләнеп авыз тутырып кызыл кесәл дә ашаганым юк. Ул башкасын әйтмим дә инде, күбекләр, бламанжиларның күптән көлләре күккә очты.* Г. Камал.

КҮБЕКЛӘНҮ *ф.* 1. Күбек барлыкка килү, күбеклегә әйләнү. *Күбекләнеп, сауган сөте ташый чиләктән.* Ф. Кәрим. *Күбекләнеп кайнаган тулкынлар гына күзгә чалынып кала иде.* С. Сабиров.

2. Авыздан күбекләр чыгу, күбекләр килү. [*Следовательнең*] *ирен кырыйлары күбекләнде, авызы, тагы нәрсәдер әйтергә теләп, бер ачылды, бер ябылды.* Г. Гобәй. [*Атларның*] *авызлары күбекләнгән, өсләрендәге тир яңа бераз ката башлаган, үзләре салмак кына атлыйлар.* Г. Ибраһимов.

КҮБЕНҮ *ф. сөйл.* 1. Су сеңдән кабарып, каты әйбернең күләме арту; бүртү. *Каралтылар, өйләр, ат юллары Яңгыр суы белән күбенгән.* Ш. Маннур.

2. Кабару, шешенү (тән турында). *Авыру* [*кешенең*] ***тышкы күренеше болай: бөтен тән күбенә һәм шешенә.*** Анатомия. *Көзгегә бакса,* [*малай*] *күрә: күгәреп күбенгән бит-башы.* М. Гафури.

3. Күп ашаудан яки бүртә торган азык ашаудан эч зураю, эч күбү, эчнең күләме зураю. *Күрми күргән күбенеп үләр.* Мәкаль. [*Бай*] *үзе ачулымы, ниме, һичкемгә һичбер сүз әйтми: кибәк ашап күбенгән сыер кебек, пую-ф... пуф-ф итеп тора.* Г. Ибраһимов.

КҮ'БЕСЕ *и.* Кемнәрнең яки нәрсәләрнең дә булса күп өлеше, күпчелеге. *Бездә таланлы, яхшы композиторлар бар һәм аларның күбесе махсус уку йортларында укып яталар.* М. Җәлил. *Такташ әсәрләренең күбесе әле дә укучыларны үзенә тарта.* Г. Нигъмәти.

КҮБЕСЕ'НЧӘ *рәв.* 1. Күбрәк, бигрәк тә. [*Каюм*] *үзенең ярты сәгать чамасы сузылган речендә күбесенчә Мостафа сөйләгән сүзләрне кабатлады.* Ш. Камал. *Әдип күбесенчә авылның бай һәм урта хәлле катлавын яза.* Г. Нигъмәти.

2. Күп вакытта, күпчелек очракта. *Күбесенчә Миңнурый укый, Газинур, бер кулын иягенә куеп, зур күзләрен кая булса да миң почмагына терәп, хәрәкәтсез тыңлап утыра.* Г. Әпсәләмов. *Бу автомобильгә күбесенчә райбашкарма председателе Галиуллин утырып йөри.* Г. Кутуй.

КҮБРӘК *рәв.* 1. *Чаг. дәр. к.* күп. *Актуш камчылар күбрәк төшкән саен күбрәк ярсыды.* Г. Гобәй.

2. Күп вакытта, күп очракта, күбесенчә. *Югары Шырдан халкы күбрәк ямщик чабып, я читтән йөреп кәсепләнеп килгәннәр.* М. Гали. *Лиза сүзгә аз катыша, күбрәк тыңлап утыра иде.* Ф. Әмирхан.

КҮ'БУРЫНЛЫ *с. мат.* Берничә цифрдан торган, берничә цифр билгесен үз эченә алган. *Күбурынлы саннарны кушуның разрядлап эшләнгәнен хәтердә тотарга кирәк.* Арифметика.

КҮБӘ I *и.* Сәнәк белән бер күтәреп алырлык итеп әзерләп куелган печән яки чабылган иген өеме. *Чапкан печәнне икенче көнне әйләндереп, кичен әлек күбәләргә, аннары инде чүмәләләргә салып була.* Г. Галиев. *Хатын-кыз күбәләрдән чүмәлә ясый.* Ә. Баянов.

КҮБӘ II: **күбә яңгыр** *диал.* — вак яңгыр, пыскак яңгыр. *Күбә яңгыр сибәләп тора.* И. Гази.

КҮБӘЙТҮ *ф.* Берәр предметның санын, микъдарын арттыру, күп итү. *Бар белгәне акча күбәйтү өчен мал кайгысы гына.* Ш. Мөхәммәдев. *Бу хәл* [*әсәрдә*] *каһарманнар санын күбәйтеп, аларны бер дәрәҗә схемалаштыруга илтсә дә, пьеса үзенең художество-сәяси актуальлеген югалтмаган.* Г. Нигъмәти.

Күбәйтү машинасы — кулъязма, сызым һ. б. ш. нәрсәләрне тиешле данәдә күбәйтү өчен хезмәт итә торган аппарат.

КҮБӘК *и.* Сап, тотка (чабагачта). *Чабагач күбәге, бозлы җиргә бәрелеп, ике җирдән дә өзгәләнде дә чыкты.* Г. Толымбай.

КҮБӘЛӘК *и.* 1. Ике якта төрле төстәге тузанча белән капланган икешәр канаты булган бөҗәк. *Җир өстеннән йомшак җылы бәреп тора, шул кояш нурында күбәләкләр шаяра, урман эченнән күке тавышы ишетелә.* Г. Бәширов. *Сандугачлар сайрый, күбәләкләр, бал кортлары чәчәкләр, агач яфраклары тирәсендә кайнаша иделәр.* Ш. Камал.

2. *күч. сөйл.* Бант рәвешендәге галстук. *Заһидулла көзгедә эшләпәле, ак якага кара-күбәләк кадаган, кара мыеклы чибәр егет шәүләсен күргәч, гаҗәпләнеп калды.* Каз. утл.

Күбәләк кар — йомшак әре кар. **Күбәләк корты** *биол.* — яралгыдан килеп чыккан, ләкин әле формасы белән күбәләккә охшамаган күбәләк личинкасы. **Күбәләк чәчәк** *бот.* — кузаклылар семьялыгыннан чәчәкләре күбәләккә охшаган үлән үсемлек; *русчасы:* мотыльковый цветок. **Күбәләк чәчәклеләр** *бот.* — кузаклылардан чәчәкләре күбәләккә охшаган үсемлекләр семьялыгы.

◇ **Күбәләк гомере** — нәрсәнең дә булса бик кыска вакыт дәвам итүе турында. *Былтыр Кавказда бик шәп исемнәр белән бик начар газеталар чыгып, үзләренә махсус күбәләк гомерләре белән шып туктадылар.* Г. Тукай. **Күбәләк күңел** — тиз гашыйк булучан күңел турында. *Яшь йөрәк күп җилкенде, күбәләк күңел күп чәчәкләр тирәсендә очынды, ләкин*

һаҗәр килде — шуның белән башкалар һәммәсе югалды. Г. Ибраһимов.

КҮБӘЛӘКЛӘНҮ *ф.* 1. Күбәләк кортыннан үсеп күбәләккә әйләнү.

2. *күч.* Күбәләк рәвеше алу, күбәләк формасы барлыкка китерү. *Көн бераз җылыта төшкән, җил дә туктаган, карны да себертми, [кар] күбәләкләнеп кенә ява башлаган.* Х. Кәрим.

КҮБӘЛӘҮ *ф.* Печән жыйганда аны күбәләргә өю, сәнәк белән күтәреп алырлык итеп өеп-өеп китү. *[Шәрәф:] Бу безнең чабын. - - - Без аны икәүләп чаптык. Әтием белән икәү күбәләдек.* М. Фәйзи.

КҮБӘЮ *ф.* 1. Саны, микъдары яки күләме, зурлыгы ягыннан арту, ишәю. *Урманда көтүне әзләп йөрүчеләр күбәйдә.* һ. Такташ. *Тракторлар күбәйгәч, [атларга] юньләп эш тә - - - калмады.* Р. Төхфәтуллин.

2. *сөйл.* Көчәю; арту. *Аның өстенә көннән-көн һөҗүм вә суз күбәя.* М. Гафури. *Тавыш бирдем - - - Илемнең көч-куәте күбәя төшсен өчен.* Ә. Ерикәй.

КҮБӘҮ *и. сөйл.* Саны билгесез күп кешеләр турында. *Хәйдәр аларны кискен җаваплар белән кайтаргач, күбәү җыелып килеп чигенүне сорадылар.* Ш. Усманов. || *хәб. функ.* Күп, күп санда. *Машинада руслар гына түгел, немецлар да, болгарлар да бар иде. Күбәү иде алар.* Г. Гобәй. *Мондый утенеч белән мөрәҗәгать итүчеләр Гөлзәбәр генә түгел, алар күбәү иде.* Г. Бәширов.

КҮБӘҮ|МЕ *сор. алм. сөйл.* Күпме, ничаклы. *[Шәйхи:] Ак чехлар күбәүме? Оста сугышалармы?* Ш. Усманов.

КҮБҮ *ф. сөйл. к.* күбенү (2, 3 мәгъ.). *Ике араны [шахтада] берничә рәт әйләнгәнче, минем баш берничә җирдән күбеп чыкты.* М. Гафури. — *Алдасам, эчем күпсен.* М. Әмир.

КҮГЕЛҖЕМ *с* 1. Беркадәр күк, көлсу күк, тоныклыгы күк. *Тирә-якта урман белән капланган күгелҗем таулар, яңа өлгереп килгән ашлык басулары күренеп тора.* А. Әхмәт. *Күгелҗем төтенне авыздан бөдрәләндереп чыгара-чыгара, ул сүзгә кереште.* Ә. Айдар.

2. Кайбер зоологик һәм ботаник терминнарның состав кисәге. *Күгелҗем суусемнәр. Күгелҗем акчарлак.*

КҮГЕЛҖЕМ-КЫЗЫЛ *с.* Күгелҗем төсмер алган кызыл, күгелҗем һәм кызыл төстәге. *[Ул] балтаның түтәсендә катып калган әллә нинди күгелҗем-кызыл пычраклар күрде.* Ш. Камал.

КҮГЕЛҖЕМЛӘНҮ *ф.* Күгелҗем төскә керү, күгелҗем төс алу. *Ерактагы кара урман, ничектер, күгелҗемләнеп, яшәреп китте.* Г. Гобәй. || Күгелҗемләнеп күренү. *Чирәм буйлап күгелҗемләнгән самовар төтеннәре дә хәзер күренми.* К. Нәҗми. *Машина, күгелҗемләнеп, кара-кучкылланып яткан Алка күлне урап, үзәк усадьбага керде.* И. Салахов.

КҮГӘЛ *и.* Кыр үрдәгенең бер төре. *Күгәл күленә күрә чумар.* Мәкаль.

КҮГӘН I *и.* Ишек, капка кебек нәрсәләрне беркетә һәм аларга ачылырга-ябылырга мөмкинлек бирә торган, ыргакка яки шарнирга утыртылган бер яки ике металл планкадан гыйбарәт җайланма. *[Өйнең] ишеге кыегаеп, бер күгәненә генә асылынып тора.* Г. Ахунов.

КҮГӘН II *и. бот.* Гөлчәчәкләр семьялыгыннан ашарга яраклы күгелҗем җимешләр бирә торган чәнечкеле куак; *русчасы:* тёрн. *Урман кырларында кыргый чия, күгән, ногыт сабагы кебекләр күренә.* А. Фаткуллин.

КҮГӘНЛЕК *и.* Күгән күп үскән урын, күгән куаклыклары.

КҮГӘРЕК *и.* 1. Тиешле дымлылык яки температура булганда, органик матдәләрдә һәм предметларда куныклык рәвешендә барлыкка килә торган соргылт-күк яки саргылт-соры төстәге микроскопик гөмбәчекләр. *Идән сайгаклары булган урында кара җир күгәрек дымлы исләрен аңкыта иде.* Г. Ахунов. *Җиләк-җимеш һәм яшелчәләр саклана торган урыннарда күгәрек, аларны күпләп черетеп, бик зур зыян китерә.* Биология.

2. *күч.* Идеологиядәге һ. б. ш. өлкәләрдәге ялгыш карашлар, таркалу элементлары турында. *Хәзер пролетариат, халыкның алдынгы көрәшчесе буларак, үзенең оешмасын нығытырга, интеллигентлар оппортунизмының һәртөрле күгәреген үзенең өстеннән кырып ташларга - - - тиеш.* В. И. Ленин.

3. Тәндә бәрелүдән күгәреп чыккан урын.

4. *диал. к.* тутык.

КҮГӘРЕНҮ *ф.* Күк төскә керү, күк төсмер алу; күгәрү (тән турында). *Төн суыгыннан Тәннәр күгәренде.* М. Җәлил. || Ачудан һ. б. ш. хисләрдән төс үзгәрү, төс бозылу. *Күгәренеп китте Гөлсем апа, кулларын калтыранды.* Г. Гобәй. *Зиннәт, ачуыннан күгәренеп, . . . акырып җибәрде.* Г. Бәширов.

КҮГӘРЧЕН *и.* 1. Күгәрченсыманнар отрядыннан дөньяның барлык кисәкләрендә диярлек таралган, гадәттә соргылт-күк яки ак төстәге кош. *Кыр күгәрчене. Почта күгәрчене.* □ *Өй кыегында кызыл күзле күгәрченнәр гөрли.* И. Гази. *Кызыл аяклы матур күк күгәрченнәрнең якты кояш астында үбешеп уйнаулары күз алдына килде.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. сөйл. ирк.* **күгәрченем, күгәрченкәем.** Күбесенчә хатын-кызларга иркәләп мөрәҗәгать итү сүзе: „сөеклем“, „кадерлем“ мәгънәсендә. *[Таһир Зөһрәгә:] Тагын кайттым сиңа, күгәрченем!* Ф. Бурнаш. *Күгәрченем, гөлчәчәгем, Хатлар көтәрмен сиңнән.* Ф. Кәрим.

Күгәрчен күзе *бот.* — кечкенә генә күк чәчәкләр ата торган үлән үсемлек; *русчасы:* незабудка. *Күгәрчен күзе даимилекне, арчан ялгызлыкны аңлаткан.* Робинзон эзл. **Күгәрчен тәпие** *бот. сөйл.* — *к.* канәфер I (1 мәгъ.). **Күгәрчен кетәге** — 1) өй яки сарай түбәсендә, чарлагында йорт күгәрченнәре өчен ясала торган кетәк, оя; 2) *күч.* театрда иң югарыдагы ярус. **Күгәрчен сөте** — 1) *бот.* казаякчалар семьялыгыннан күк яки ал чәчәк ата торган үсемлек; 2) *күч. сөйл. ирон.* аракы, спиртлы эчемлек. *[Газинур:] Әлфия, кызарма, күгәрчен сөтеңне хәзерләп куй, кунакка килермен.* Г. Әпсәләмов. **Күгәрчен чәчәге** *бот.* — әре күгелҗем чәчәкле үлән үсемлек.

◇ **Күгәрчен кебек гөрләшеп яшәү (гомер итү)** — бергә бик дус яшәү, бик тату яшәү. *[Гайнулланың] унөч ел бергә күгәрчен кебек гөрләшеп гомер иткән Сажидәсен күрәсе килде.* А. Әхмәт. **Күгәрчен кебек гөрләү** — бик ягымлы итеп әкрен генә сөйләү. *Әпипә - - - колак төбендә күгәрчен кебек гөрләргә тотынды.* Г. Бәширов. **Күгәрчен сөте генә юк** — җитешлекне, муллыкны яки табынның бик бай хәзерләнгәнлеген белдерү өчен кулланыла.

КҮГӘРҮ *ф.* 1. Күк төскә керү, күк төс алу. *Карасана, былбыл, читлегеңнән: Урал тавы тора күгәреп.* Ш. Бабич. *Күгәрә, яшәрә бердән авыл әйләнәсе, кырлар.* М. Гафури.

2. Дымлылыктан, җылыдан яки башка шундый сәбәпләрдән күгәрек барлыкка килү. *[Артельщик] кеше башына икешәр-өчәр кисәк күгәреп, каешланып беткән кара икмәк сохарие өләшеп чыкты.* М. Гали. *[Бай:] Монда бер кибетчедән күгәрә төшкән он алган идек, шуны сезгә җибәрдек.* Ш. Мөхәммәдев.

3. *диал.* Тутыгу, тутык белән каплану. [*Урәтник*] *күгәргән кылычы белән халыкны куарга тотынды.* К. Нәҗми.

4. *күч.* Тормыштан артта калу, артка калган кешегә әйләнү. [*Солтан:*] *Йөргән таш шомара, мин монда күгәреп ятам.* Г. Ибраһимов. || Каты күнеллегә, туң йөрәклегә әйләнү; үзенең жәнлылыгын югалту (бу мәгънәдә күбрәк „йөрәк“ сүзе белән килә). *Мондый бөдрә язларда кемнең генә йөрәге дәртләнмәс икән. Нигез ташы белән бергә күгәреп каткан, мукләнгән йөрәкләр генә дәртләнмәсә дәртләнмәсләр.* А. Шамов. [*Карт солдат:*] *Ачлы-туклы салкын окопларда ята-ята, безнең йөрәкләргә йон үсеп, күгәреп бетте инде.* М. Гали.

Күгәреп яту (тору) — күк булып күренү, күгәреп күренү. *Анда тик күгәреп яткан диңгез шикелле сахра гына күренә.* Г. Тукай. *Ахрысы, сакал-мыек бик куе үсмәкчедер, нык кырылса да,* [*Шаһбазның*] *яңаклары, мыек урыннары бераз күгәреп торалар.* Г. Ибраһимов.

◇ **Күгәреп беткән тавыш** — карлыккан тавыш. *Озын йонлы карт этләр үзләренең күгәреп беткән тавышлары белән өрергә тотындылар.* С. Җәләл.

КҮЗ *и.* **1.** Күрү органы. *Кара күзләр. Зәңгәр күзләр. Күк күзләр.* □ *Яшь күз турырак күрә.* Ш. Усманов. [*Карчык:*] *Минем күзләрем төс аермыйлар инде, кызым, карасын алып кил.* А. Әхмәт. || Күрү сәләте. [*Егор:*] *Әллә нигә күз начарланып китте, мишеньга дөрес бәрми.* Г. Гобәй. *Күзе үткен икән, ул башлап мине танып алды.* М. Гали. || Күз карашы. *Егет белән ара-тирә читән аша яки тәрәзә аркылы күзләр очрашкан саен, аның йөрәге дулкынланып, тәне кайнап китә.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Күзләрне дәвалаучы. *Күз врачы.*

2. *күч. сөйл.* Караш; билгеле бер мөнәсәбәт. [*Вак милекче крестьян*] *һәммә нәрсәгә „баю“ күзеннән карый.* Г. Нигъмәти. *Баштарак моңа түбән күз белән караган, үзе белән бер класста укыган укучылар да аны арага алырга тырыша башлыйлар.* М. Гали.

3. *күч.* Кемнең дә булса игътибары, күзәтеп торуы турында. *Бөтен халыкның күзе сиңдә.* Ф. Хөсни. [*Ильяс:*] *Монда кемнең дә булса бер жаваплы кешенең күзе кирәк.* Р. Ишморат.

4. *күч. сөйл.* Күзәтеп торучы, күзәтче (2 мәгъ.). *Тукта, ниләр кыланып ята икән, - - - дигәндер. Күз жибәрим янына, тыныч кына ятмасын, дип хафаланган дыр.* Ш. Маннур.

5. *тарт. форм.* Берәр нәрсә (мәсәлән, кояш, жил) тәэсиренә дучар булган урынны, жирне белдерә. *Кояш күзенә ашлык жәю.* □ *Жил күзендә утырган буш корпусны үтеп чыгам дигәндә, аны Гәүһәрия куып житте.* А. Гыйләжев.

6. *сөйл.* Икмәк, сыр һ. б. ш. нәрсәләрдәге кечкенә тишек, ' буш урын, күзәнәк. *Тәлинкәдә — кояш, Тастымалда — икмәк, Телем күзләренә нур тулган.* Р. Фәйзуллин.

7. (Оек, бияләй һ. б. ш. нәрсәләрне) бәйләгәндә бер-беренә эләктерелеп бара торган, жептән гыйбарәт элмәк. *Оекның күзе китү.* □ *Күзләр санын арттыру кирәк булганда, өстән бер күз өстәп, бер күзне генә бәйләп алалар.* Йорт эшләре.

8. Туку станогында буйлык (буй жепләр) үременең һәрбер төене.

9. *тарт. форм.* Нәрсәнең дә булса нәкъ уртасы. *Парадный баскычыннан сикереп үк киткән идем — ике аяклап, бик нык иттереп, нәкъ су жыентыгының күзенә төшкәнмен.* Ш. Камал. *Яфрак белән капланган су ятмаларының күзенә генә басабыз.* А. Гыйләжев. || *сөйл.* Су өстендә боз эреп ачылган урын. *Боздагы күзләр.* || *сөйл.* Пешерелгән ботканың уртасына ясалып, май салынган чокыр. *Ботка күзе.*

10. *сөйл.* Энәнең юанрак башында жеп саплау өчен ясалган тишек. *Энә күзе.* || Кул тегермәненең өске ташында ашлык сала торган тишек. — *Гомре тегермән тарткан, күзенә* [*бөртек*] *сала алмаган.* Н. Исәнбәт. || Гомумән кайбер предметларда махсус эшләнгән кечкенә генә тишек. *Ачкыч күзе. Төймә күзе.* || Тоткыннарны күзәтү өчен төрмә камерасы ишегендәге кечкенә тишек. *Надзирательләр, минут саен диярлек тимер ишекнең кечкенә тимер күзен ачып, сагалап кына йөриләр.* Г. Ибраһимов.

11. *сөйл.* Тәрәзә өлгесе, тәрәзә рамындагы бер өлге. [*Әхмәтжан:*] *Егермеләп тәрәзә рамын яңадан ясарга, иллеләп рам төзәтергә, йөз күздән артык пыяла куярга, биш йөз күз пыяланы замазкаларга кирәк.* М. Гали. *Өйнең ишек алды ягына караган бер стенасында кечкенә генә дүрт күзле бер тәрәзәсе бар.* З. Бәшири.

12. *сөйл. к.* күзчә (2 мәгъ.). *Бәрәңге күзе.* || Бәрәңгенең күзчәләрен кисеп алып әзерләнгән орлык. *Аннары бәрәңге күзләре дә хәзерләргә кирәк.* Соц. Тат.

13. *гади с.* Комарлы карта уенында картадагы билгеләрнең оту өченкирәк булган саны, дәрәҗәсе; егерме бер, очко. *Кайбер солдатлар күзенә бер тиен генә салып уйнасалар да, бер сәгатьтә 75 тиеннәрен калдырып, читкә китеп утырдылар.* М. Гали.

14. *ирк.* **күзем.** *к.* күзалмам. [*Мостафа*], *„Анам, жаным, күзем...“ дип, акырып-акырып елый.* Ш. Камал.

15. *сөйл.* **күздә.** „Якты“, „караңгы“ кебек сүзләрдән соң килеп, „вакытта“, „вакытында“ дигән мәгънәне белдерә. *Ашъяулык әйләнәләрендә исә, якты күздә эшне бетерергә кирәк дип, кызу „эш“ барган чак иде.* Г. Бәширов. *Кайчандыр кышның караңгы күзендә, сукыр лампа яктысында, зур мәшәкать белән Габдулланың бабасына язылган хат исләреннән үк чыккан.* Ә. Фәйзи.

16. *рәв. мәгъ. чыг. килеш форм. сөйл.* **күзеннән.** Мөлдерәмә, түгелерлек дәрәҗәдә (тулып). *Әнкәй ала сыерны үз урынына кертеп яба һәм күзеннән булып сөт белән тулган, өсте ак кисәя белән ябылган ак чиләген күтәреп өйгә таба юнәлә.* Г. Галиев.

17. *рәв. мәгъ. юн. килеш форм. сөйл.* **күзгә.** Карап торуга, читтән караганда, тышкы күренешеге ягыннан. *Күзгә чибәр генә.* □ *Күл бик тирән, Күзгә сай күк ләкин.* Б. Рәхмәт.

18. *бәйл. функ. у.-вак. килеш форм. сөйл.* **күзендә.** Алдында, күз алдында. *Халык күзендә.* □ *Ил күзендә мине хурладың.* Ф. Бурнаш.

Күз агачы — туку станында буй жепнең койрык өлешен беркетү өчен хезмәт итә торган деталь. **Күз агы** — күзнең үтә күренми торган ак тышчасы. **Күз алмасы** — күзнең күз чокырына урнашкан шар формасындагы өлеше. *Биюченең күз алмасын кара: Ничек дәһшәт - - - яна.* Ф. Бурнаш. **Күз бәйләш** — уйнаучыларның берсе, күзе бәйләнгән килеш, башкаларны тотудан гыйбарәт уен. [*Сәрби:*] *Йөзек салыш, - - - бармак санаш, күз бәйләш, йөзек яшереш уеннары уйнарбыз.* Ф. Бурнаш. **Күз кабагы** — кирәк вакытта күз алмасын каплый торган аслы-өсле тире жыерчасы. *Күз кабаклары, авыраеп, ихтыярсыз йомыла башладылар.* Г. Гобәй. **Күз карасы** — 1) күз алмасының эченә яктылык нуры үтеп керә торган, мөгез катлауга урнашкан тишек; бәбәк. *Гитлер явын тар-мар итми торып, Якты күрмәс күзем карасы.* М. Жәлил; 2) *күч.* „бик кадерле кеше“, „бик якын кеше“ мәгънәсендә кулланыла. [*Вәзир:*] *Кичер минем күзем карасын, Аяу кирәк ата баласын.* Ф. Бурнаш. **Күз тәбә** — табада йомырканың агы белән сарысы тугланган

мыйча пешерелгән ашамлык. [*Трактирчы:*] *Теләсәгез йомыркадан күз тәбә салып бирергә була.* М. Гали. **Күз төбе** — күзнең аскы кабагына якын өлеше. *Тоткын балалар элеккегә караганда да сәләмләнә төшкәннәр, кыйналудан йөзләре, күз төпләре күгәргән.* А. Әхмәт. **Күз чокыры** — баш сөягендә күз алмасы урнаша торган тишекләр. *Күз чокыры тирән батынкылык булып, анда үзенең нервлары, кан тамырлары һәм мускуллары белән күз алмасы урнаша.* Анатомия. **Күз яше** — кайбер физиологик хәлләр яки психологик кичерешләр вакытында күздәге бизләр тарафыннан бүлеп чыгарыла торган үтә күренмәле, төссез, беркадәр тозлы сыекча. *Фашист явызлар ирләребезнең каннары, безнең күз яшьләребез өчен тормышлары белән җавап бирерләр, ә без яшәрбез.* Р. Ишморат. **Күз үләне (уты)** *бот.* — сыраҗчалар семьялыгыннан бик ачык чәчәкле берьеллык болын үләне; *русчасы:* очанка лекарственная.

◇ **Күз агы кебек саклау** — *к.* күз карасы кебек саклау. **Күз агым** — иң кадерле, сөекле кешегә карата иркәләп әйтелә. [*Габдулла:*] *Син, Закир, миңа менә шушы күз агым — бердәнбер кызым Галия кебек үк кадерлисең!* Ак юл. **Күз акаю** *гади с.* — күзләр зур булып ачылу (бик нык гаҗәпләнүдән, ачуланудан, куркудан һ. б. ш). *Иртә белән майга дип Керсәм, күзем акайды; Явыз песи берүзе Ялт иттергән ак майны!* М. Җәлил. **Күз алакаю** *гади с.* — *к.* күз алару (1 мәгъ.) [*Сиражетдин:*] *Болай булганда үзләренең дә күзләре алакаер. Биргәнне тизрәк алып калырга тырышырлар.* Г. Камал. **Күз алару** — 1) бик зур теләк барлыкка килү, нәрсәне дә булса кулга төшерергә теләү. *Акчаны күргәч, хатынның күзләре аларды, төшемме, өнемме дип, кире чигенде.* Г. Ибраһимов; 2) куркудан нишләргә дә белмәү. *Чынлап та, хәзер бу кешенең күзләре аларган, йөзе агарган, үзе соң дәрәҗәдә куркыныч бер кыяфәткә кергән иде.* М. Гафури. **Күз алды (аллары) караңгылану (чуарлану)** — хәлсезлектән яки көчле дулкынланудан вакытлыча ачык күрү сәләтен югалту, күз күрмәс булу. *Күз аллары караңгыланды ананың, башы әйләнде, чайкалып ава башлаган гәүдәсен тотып калу өчен тәрәзә челтәренә ябышты.* Г. Гобәй. *Минем күз алларым чуарланды, гәүдәм авырланып китте.* Ш. Камал. **Күз алдына килү (килеп басу)** — күзаллауда, уйда, хыялда барлыкка килү; кем яки нәрсә турында да булса күзаллау барлыкка килү. *Уткән вакытлар, андагы хәрәкәтләр, эшләгән эшләр — һәммәсе гәүдәләнде... ялгыз баруым күз алдына килде.* М. Гафури. **Күз алдына китерү (китереп бастыру)** — фикердә-уйда образлар барлыкка китерү, фикердә-уйда гәүдәләндерү; күзаллау. *Аның сөйгәне Гәүһәр туташны җанлы көенчә күз алдына китереп бастырдым.* Г. Ибраһимов. *Габдерраззак бабасын шул рәсемдәге батыр кыяфәтендә күз алдына китерде.* М. Гали. **Күз алдында**—1) кемнең дә булса алдында, каршысында. *Күз алдымда кызыл канатларын кабарткан, авызын ачкан алабуга торса да, сүзем икенче булды.* А. Әхмәт; 2) сизелеп, сизелерлек булып. [*Ләмига түтәй:*] *Күз алдында үзгәрде бит малай, әтисе кайткач танымас та инде.* Г. Гобәй; 3) *к.* күзгә карап. *Күз алдында ялганлау*; 4) үзе барда, үз алдында. *Күз алдында мактау*; 5) кемнең дә булса күзаллавында. [*Газизов:*] *Күз алдымда бары шул цифрлар гына йөрде.* А. Шамов. **Күз алдында йолдызлар уйнау** — *к.* күздән (күзгә) ут күренү. **Күз алдында тоту** — *к.* күздә тоту. [*Сәмигуллин:*] *Кулак һәм кулак иярченнәренең советка каршы дошманлык чыгышы ясау ихтималларын сез һәрвакыт күз алдында тотарга тиешсез.* Ш. Камал. **Күз алдында тору** — *к.* күз алдыннан китмәү. **Күз алдыннан китмәү** — истән чыкмау, һәрвакыт истә булу; уйда-фикердә булу. *Үзебезнең өй кешеләре, бигрәк тә әни, күз алдыннан китми.* М. Гафури. **Күз алдыннан уздыру (кичерү)** — бер-бер артлы күз алдына китерү. *Габденнасыйр Зөягә барып җиткәнче толып якасы эченнән берәм-берәм шуларны күз алдыннан уздырды.* М. Гали. **Күз алдыннан узу (кичү)** — бер-бер артлы күз алдына килү. *Зуры да, вагы да, кирәге дә, кирәкмәсе дә — һәммәсе тикшерүченең күз алдыннан кичте.* Г. Ибраһимов. **Күз алларын томалау** — дөньяга дөрес караш булдырырга мөмкинлек бирмәү. [*Нәфисә:*] *Дин сөреме бездә кайберәүләрнең әле шушы көнгә кадәр күз алларын томалап тора.* Г. Бәширов. **Күз алмам** — *к.* күзалмам. *Күз алмам-әтием доктор иде, ул үз гомерендә төрле-төрле дарулар ясады, күп кешеләрне үлемнән коткарды.* А. Алиш. **Күз(не) алмау** — кемгә яки нәрсәгә дә булса өзлексез, озак итеп карау, карап тору. *Илдар белән Марат аңардан күзләрен алмадылар.* Г. Гобәй. *Без вагонда киң кырлардан Күз алмыйча барабыз.* Ә. Еникәй. **Күз алмашу** — күз дөрес күрми башлау, күз ялгышу. *Ул арада караңгылык төшеп, урман эчендә күз алмаша башлаган.* Г. Рәхим. *Бара торгач, әллә нишләп күз алмаштым, Карап торам: кыз илә саз күккә аштым.* М. Гафури. **Күз алышу** — кем белән дә булса карашу, карашып алу. [*Гайнетдинов*] *крестьяннар, хатыннар, кызыл гаскәрләр белән күз алыштым.* Г. Ибраһимов. **Күз артында** — үзе югында, үзе катнашмаганда (сөйләү, тиргәү һ. б.). **Күз астында** — кем дә булса карап торган вакытта; күзәтү астында. *Бөтен халык күзе астында.* **Күз ату** — 1) карау, карап алу; күз төшерү. *Җиһангир - - - сакланып шул хатынга күз атты да кире бакча эченә чигенде.* Г. Ибраһимов; 2) *к.* күз төшү (2 мәгъ.). *Күз аттым мин бүген бер шәп кәләшкә.* Г. Тукай. **Күз атып йөрү** — кемне дә булса ярату, кемгәдер берәүгә сөю хисе булу. [*Нәфисәгә*] *күз атып йөрүче егетләр аз түгел иде.* Г. Бәширов. **Күз ачарлык (та) түгел** — *к.* күз ачкысыз, күз ачмаслык. [*Әхмәдулла:*] *Ай-яй буран, - - - станциядән чыгып бераз киткәч тә шундый күтәрелде, күз ачарлык та түгел, - - - көчкә килеп җиттем.* А. Шамов. **Күз ачкысыз, күз ачмаслык** — бик көчле, бик каты (буран, кар һ. б. ш. турында). *Юлга чыкканда күз ачкысыз буран һәм салкын иде.* М. Гали. **Күз ачылу** — кемнең дә булса **берәр** нәрсәне аңлый башлавы, дөреслекне төшенүе турында. — *Күзем ачылган саен, фикерем киңәйгән саен, шатлык, тынычлыклар урынына, башым төрле кайгылар, хәсрәтләр белән тула бара.* Г. Коләхметов. **Күз ачып йомганчы (күз ачып, күз йомганчы)** — бик тиз; кинәт. *Мәрдән абзый күз ачып йомганчы ишектән чыгып китте.* Г. Гобәй. — *Күз ачып, күз йомганчы дүрт-биш арбаны бушатып та[1] ташлыйбыз.* Г. Ибраһимов. **Күз(не) ачырмау** — әрләү, битәрләү, тиргәү. [*Габдулла:*] *Кызлар күземне ачырмый, йөкле хатыннарны кырга чыгармасаң, колхозда кеше беткәнмени, диләр.* Г. Әпсәләмов. *Күз ачырмас, Сафи абзыйны талар; әллә кайдан фетнә чыгарыр, табар.* Г. Тукай. **Күз белән сөзү** — бик җентекләп карау, бик нык карау. [*Габденнасыйр*] *бүлмәне яңадан бер кат күзе белән сөзеп чыкты.* М. Гали. **Күз(не) бетерү (бетәштерү)** — күзнең күрү сәләтен киметү, күзне бозу. [*Гөлгенә түти:*] *Безнең шикелле, күз бетәштереп, биш тиенлек көмеш тәңкә кебек тиреләрне ялгап утырмыйлар.* М. Гали. **Күз бетәшү (бетү)** — күзнең күрү сәләте кимү, күз бозылу. *Габдулла [өйнең] - - - зур-зур ләгәннәр, комганнар, сөлгеләр, иске туннар белән тулган кара ягында күзләре бетәшкән карт бер әби белән бергә яшәде.* Ә. Фәйзи. **Күз буу** *иск.* — 1) сихерләү; 2) гипнозлау,

гипноз йогынтысына дучар итү. [*Хәзрәт:*] *Әле кул алышмыйча күземне буа алмыйсыңмыни?* Ф. Әмирхан. **Күз буучы** *иск.* — 1) сихерче, сихерләүче. [*Әхмәт:*] *Җиде кат җир астында елан йөргәнне сизүче, күз буучы, кешенең киләчәген күрүче - - - мин буламын.* Д. Аппакова; 2) гипнозчы, гипнозлаучы. **Күз буяу** — алдау, кемнән дә булса дөреслекне яшерү; юк нәрсәне бар дип күрсәтү. [*Садыйк:*] *Шуннан соң болар, Галләмнең күзен буяр өчен булырга кирәк, - - - ат белән кеше җибәреп, шәһәрдән солдат кыяфәтле кешеләр алып килделәр.* Ш. Камал. [*Йөзлебикә*] *Сәйфинең күз буяуларын, эчеп йөрүләрен күзенә терәп сөйләп китте.* Г. Бәширов. **Күз буяучы** — алдакчы, ялганлаучы. [*Иван Михайлович:*] *„Кызыл таң“ хуҗалыгы күз буяучылары, билгеле, өлешсез калмас.* С. Рафиков. **Күз бәйләнү** — караңгы төшү, эңгер-меңгер вакыт җитү. [*Ул*] *күз бәйләнгәнче казармага җитәргә ашыкты.* К. Нәҗми. *Күз бәйләнгән вакытларда чык син күл буена.* Жыр. **Күз дә йоммыйча** — 1) икеләнмичә, шикләнмичә; курыкмыйча. *Сарсымбай, күзен дә йоммыйча, санап, картка йөз сум алтын бирде.* Г. Ибраһимов; 2) тартынмыйча, оялмыйча. **Күз дә каш урынына күрү** — бик кадерләү; бик кадерле дип санау. **Күз дүрт булу** — бик нык гажәпләнүдән, көтелмәгән шатлыктан яки куркудан күзләр зур булып ачылу. *Малайның күзе дүрт булды.* Г. Толымбай. **Күз ияләшү (өйрәнү)** — 1) караңгыда күз күрә башлау, шәйли башлау, караңгыда күрергә күз җайлашу; 2) күнегеп бетү, өйрәнеп җитү; күзгә ят күренмәү. *Аның бу әллә кайчан күз ияләшеп беткән ферма каралтыларына һәм анда эшләп йөрүчеләргә башкачарак, беренче тапкыр күргән кебегрәк карыйсы килде.* Ә. Еники. [*Вахит*] *берәр атнадан тагы шул җиргә килеп, борынгы, күзе өйрәнеп, күңеле күнегеп беткән эшкә кереште.* М. Гафури. **Күз (дә) иярми** — бик тиз хәрәкәт итү, җитез эшләү турында. [*Вагоннарның*] *соңгы берничәсе шулкадәр кызу узды, алар артыннан күз иярми башлады.* Г. Гобәй. *Кулларына күз иярми иде, Йөгерә-йөгерә җиләк җыйганда.* Ә. Ерикәй. **Күз иярмәс(лек) тизлек белән** — бик зур тизлек белән. *Тау кырыйларында, каралты түбәләрендә күз иярмәслек тизлек белән җылы дулкыннары тибрәнә.* Г. Бәширов. *Күз иярмәс тизлек белән Айкап кылычын, Үтә егет киң урамнан Кош кебек очып.* Ф. Кәрим. **Күз йома алмау** — йоклый алмау. **Күз(не) йоммау** — йокламау, бер дә йокламау. *Апалар бу төнне күзне дә йоммады.* Г. Ибраһимов. **Күз йомдыру** — алдау. **Күз йому** — аңлы рәвештә игътибар итмәү, белә торып игътибар итмәү; күрмәмешкә салыну. *Сөйгәнемнән шүрәле төсле качам, Юлда күрсәм, күз йомам, күрмим имеш.* Г. Тукай. **Күз йомып алу** — йоклап алу, черем итеп алу. *Җыелышка вакыт иртәрәк әле. Азрак күз йомып алырга мөмкин.* Ш. Камал. **Күз йомып тору** — эндәшмәү, игътибар итмәү; түзү. [*Гарифҗ:*] *Безгә күзләребезне йомып торырга ярамас. - - - Ак бандитларның ояларын туздырырга кирәк.* Ш. Камал. **Күз(не) йөртү (йөгертү)** — кемне яки нәрсәне дә булса өстән-өстән генә карау, тиз генә карап чыгу. *Нуруллин бөтен тирә-юньгә күз йөртеп чыкты.* А. Шамов. *Кеше, балаларның ашыкканнарын күреп, бер рәсем янында да тукталып тормады, нәрсәдер эзләгән кебек, күзләрен йөгертеп кенә үтте.* Г. Гобәй. **Күз (кабагы) тарту** — хорафат карашлар буенча: киләчәктә буласы берәр төрле шатлыкны яки күңелсезлекне белдерү билгесе дип санала. *Ике күзем парлап тартса, хәсрәтем артадыр.* Жыр. [*Шәмсия:*] *дәтәм аны ике-өч көннән бирле сул күз кабагым тарта иде, шуңа икән.* Т. Гыйззәт. **Күз кайту** — күзнең күрү сәләте кимү, күзнең күрү сәләте начарлану, күз начарлану. *Карчык бөтенләй үк сукыр булмаса да, күзе кайткан кеше булса кирәк.* Әкият. **Күз калайлану** — күзнең киеренке хәлгә килеп, көчле теләкне, хисне белдерүе турында. **Күз калмау** — 1) күз ару, күз талчыгу; 2) күзнең күрү сәләте кимү (күп уку, елау һ. б. ш. сәбәпләр аркасында). **Күз камаштыргыч** — күзләрне тутырып ачарга комачаулый торган, күзләрне чагылдыра торган (яктылык һ. б. турында). *Анда шатлык, анда нур, Анда бәхетле бәндәләр, Күз камаштыргыч сибелгән Анда нурлар, шәүләләр.* Һ. Такташ. **Күз камашу** — *к.* күз чагылу. [*Пәкенә*] *озынлы-кыскалы биш корыч пычагы бар. Берсеннән-берсе үткен, ялт та йолт киләләр. Күзең камашырлык.* Д. Аппакова. **Күз карасы кебек саклау, күз карасыдай саклау** — бик тырышып саклау, кадерләп тоту. *Пионер законы: „Пионер җәмәгать милкен күз карасы кебек сакларга тиеш“.* А. Алиш. **Күз карасын түгеп карау (карап калу)** — бик нык йотылып карау (карап калу). **Күз карашка** — тышкы кыяфәтенә караганда. [*Хажи:*] *Юкса, күз карашка бер дә алай яшь кебек күренми иде.* Ш. Камал. **Күз карашы** — 1) кемгә яки нәрсәгә дә булса күз төбәү, карау. *Без сөйләшеп түгел, серебезне Күз карашы белән аңлаттык.* М. Җәлил; 2) кешедәге эчке халәтнең чагылышы буларак, күзнең күренеше. *Карчыкның чырае җансыз, күз карашыннан кыш салкыны бәрелеп тора иде.* Г. Бәширов. **Күз кушыру** *диал.* — карау, күзләрне төбәү. **Күз кызу** — кызыгу, теләү; теләк уяну. *Шәһәрнең матур мәгаллимәсе Камиләгә карт хаҗиның күптән инде күзе кызып йөри.* Г. Нигъмәти. **Күз кырые белән карау (күрү һ. б.)** — йөзне икенче бер якка табан тотып, күз карашын сиздермичә генә берәр кешегә яки берәр нәрсәгә юнәлдерү турында. *Зәйнәпбану, тагын да кызара төшеп, күз кырые белән Нәфисәгә карап алды.* Г. Бәширов. **Күз кырыен (читен) төшерү** — йөз белән борылмыйча, күзләрне генә юнәлтеп карау, күзнең бер чите белән генә карау, карап алу. *Фельдфебель аларның аякларына күз кырыен гына төшерде.* М. Гали. **Күз кысу** — нинди дә булса бер билге яки ишарә буларак, күз кабагын хәрәкәткә китерү. *Хәлне аңлап алган шадра Йосыф Габдуллага күз кысты.* Ә. Фәйзи. **Күз көеге** — нинди дә булса эшкә комачаулаучы, күңелгә начар тәэсир итә торган берәр кеше яки нәрсә турында. [*Хәмит:*] *Эшләгән кешеләрне карап торып, аларга күз көеге булыйммы?* Р. Ишморат. **Күз(ләр) күгәрү** — көтә-көтә зарыгу, зарыгып бетү. [*Маһруй:*] *Аны көтсәң, күзең күгәрер.* М. Фәйзи. **Күз күргән** — таныш, электән таныш булган, билгеле булган. *Йола буенча, читтән кайткан кунак белән беренче чәй күз күргән якын кешесез эчелми иде.* Ә. Еники. **Күз(е) күргән якка** — теләсә кайсы якка, юлны сайлап тормыйча. [*Карт:*] *Атыңны эләктерер дә күзе күргән якка сызар.* Ш. Камал. **Күз күреме** — күз күрә алган кадәр, күз күрә алырлык (ераклык, җир һ. б. турында). [*Җәлә:*] *Көрәнем тегеләрне күз күреме җир калдырып килде.* Г. Ибраһимов. **Күз күреме җитмәс(лек)** — күзләр белән күреп бетерә, инләп ала алмаслык. *Күз күреме җитмәслек, очынакырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәшеп үләннәр үскәннәр.* А. Алиш. *Күз күреме җитмәс киңлеккә җәелгән бу зур шәһәрнең утлары кабынган.* М. Хөсәен. **Күз күрер** — нишләргә кирәклеге алда билгеле булыр; ачыкланыр. [*Нәфисә:*] *Урак өстендә анысы күз күрер әле, кем кемне биетер бит.* Г. Бәширов. **Күз күрмәгән** — сөйләүче кеше өчен таныш булмаган; сөйләүче кеше ул җирдә булмаган. *Без китәбез чит илләргә, Күз күрмәгән җирләргә.* Жыр. **Күз күрмәгән, колак ишетмәгән** — искиткеч; гадәттән тыш; моңа кадәр күрелмәгән һәм ишетелмәгән; бөтенләй таныш булмаган. *Әллә нинди күз*

күрмәгән, колак ишетмәгән товарлар белән тулган кибетләрнең алдында, умарта корты кебек, халык шаулый. Г. Ибраһимов. **Күз күрмәслек, колак ишетмәслек** (җир һ. б.) — ерак. [*Гали:*] *Бабаем, остазым, күз күрмәслек, колак ишетмәслек җиргә китәбез бит без.* Д. Аппакова. **Күз күрсә дә, кул җитми** — „ирешеп булмый", „хәлдән килми" мәгънәсендә кулланыла. **Күзләр белән ашау** — тартынмыйча туп-туры карау; йотылып карау. **Күзләр күмергә әйләну** — зарыгып көтү, озак көтү. **Күзләр мәңгегә йомылу** *юг.* — үлү, вафат булу. *Ләкин, искиткеч хәл, аның күзләре мәңгегә йомылмаган икән.* Г. Бәширов. **Күз(ләр) мутлану** — хисләр уяну, шаянлану, шаянга әйләнү (берәр кеше турында). *Кырый урамнарга бастымы, Шәмсетдиннең күзе мутлана.* Г. Бәширов. **Күз нурым** — *к.* күз алмам. [*Локман:*] *Балам, күз нурым, мин сине бераз аңлыйм, ләкин бөтенләйгә аңлап җитмим бугай.* Ш. Камал. **Күз нуры түгү** — күз белән бик җентекләп, тырышып карау; шулай карап күзнең күрү сәләтен киметү. — *Анагыз сезне укытыр өчен, көннәр буе күз нуры түгеп, бай хатыннарына күлмәк теккән.* Г. Ибраһимов. **Күз очкынлану** — тирән хис, теләк һ. б. ш. чагылышы буларак, күз ялтырау. *Аның күзләре кинәт очкынланып китте.* Г. Гобәй. **Күз очы белән, күз очтан** — сиздермичә, читләтеп кенә. *Ул кыз да, башын бераз күтәребрәк, күз очлары белән Галигә карап көлемсерәде.* Ф. Әмирхан. **Күз салу** — 1) карау, карап алу. *Мохтар, урыныннан торып, механик рәвештә урам тәрәзәсенә барып күз салды.* Ш. Камал; 2) нәрсәгә дә булса игътибар итү; аның белән танышу, аны тикшереп карау. *Җамали куркудан шашкан бичара Сафураның бу мәшәкатьләренә күз салмады.* Г. Ибраһимов. *Инде бишенче елның бирге ягына чыгып, Галимҗан Ибраһим иҗатына күз салыйк.* Г. Нигъмәти. **Күз сирпү** — күзнең кырые белән генә яки тиз генә карап алу. [*Кызлар*] *керфек асларыннан гына аңа күз дә сирпеп куйгалыйлар.* Ф. Хөсни. *Гайшә җиңги аска карап утырган иренә күз сирпеп алды.* Г. Әпсәләмов. **Күз суын түгү** — *к.* күз яше түгү. **Күз ташлау** — 1) карау, карап алу. [*Хәйдәр*] *ут әйләнәсендә күңелле түгәрәк булып тезелешеп утырган дуслар арасыннан Нәфисәгә күз ташлый.* Г. Бәширов; 2) кемне дә булса ошату, ярату, аңа күз төшерү. *Авылда Рәүфәгә күз ташлаган, сүз салган егетләр дә юк түгел иде.* А. Шамов. **Күз терәп** — өмет белән, нәрсә дә булса өмет итеп; ышанып. *Башка барыр һич урын юк Бу хатынга, күз терәп.* М. Гафури. **Күз тидерү (тигезү)** — *к.* күзектерү. [*Сөнгать:*] *Карамагызсана туры, --- күз тигезерсез.* М. Фәйзи. [*Әптелвәли:*] *Җиһангәрәйгә урын җәеп бир, --- ял итсен, күп карап, я күз тидерерсең.* Г. Толымбай. **Күз тимәсен (тия күрмәсен)** *кер. сүз.* — „кемне яки нәрсәне дә булса мактаудан, кемнән яки нәрсәдән дә булса сокланудан аңа зарар килмәсен, аңа начар булмасын" дигән мәгънәдә кулланыла (нигезендә элекке хорафат карашлар ята). — *Күз генә тимәсен, быел уҗымнар да, сабан ашлыгы да бик әйбәт өметләр тудыра.* Г. Әпсәләмов. **Күз тию** — *к.* күзегү. — [*Габдуллага*] *күз тигәндер, имләп кararга кирәк, — ди Мәгърифә карчык.* Ә. Фәйзи. **Күз(ләр) тону** — 1) күз аллары караңгылану, күз күрмәс булу. *Мәйданга килеп кердек дигәндә генә күзләрем тонып китеп, әллә нәрсәгә сөртенеп, мин шап итеп җиргә егылдым.* М. Гали; 2) күзгә бернәрсә дә күренмәү, күзгә ак-кара күренмәү (нәрсәгә дә булса җитди караш белән карарлык хәлдә булмаган кеше турында). *Әйләнәм дә сезгә киләм, әллә күзләрем тонган.* Җыр; 3) *к.* күз(ләр) күгәрү. **Күз(ләр) тору** — куркудан **яки** гаҗәпләнүдән күзләр зур ачылу. *Аны ишеткәч, безнең әбиләрнең күзләре торды, куркыша башладылар.* М. Гали. **Күз тоту** — 1) исәп итү, исәп тоту; берәр нәрсәне алдан чамалау. *Ә бабайның күз тотып йөргән участогы да бар икән.* Ә. Еники; 2) күңел төшү, ошату. — *Хәлил дә йокламаган, бөтен тирәюнь егетләре күз тотып торган кызның күңелен бәйләп өлгергән.* М. Фәйзи. **Күз туймау** — берәр нәрсә җитәрлек булса да, һаман канәгать булмау. *Үзе туйса да, күзе туймаган.* Әйтем. **Күз тышта калу** — яктыдан өйгә кергәч, беркадәр күз күрми тору. **Күз(не) төшерү** — 1) кемгә яки нәрсәгә дә булса карау. — *Шул чак Хәйбулла аның аякларына күз төшерде.* Ш. Камал; 2) игътибар итү. *Әгәр без Мәҗит Гафуриның бу чордагы әсәрләренә күз төшерсәк, аның милли азатлык өчен көрәшне чынлап та самодержавиегә һәм империализмга каршы куелган хәлдә аңлавын күрәбез.* М. Җәлил. **Күз төшү** — 1) карау. *Газизә лампага ут алындырып өстәлгә куйганда, яңа кунакның кулына күзе төште.* Ш. Камал; 2) күңелгә ошау; берәр кешегә мәхәббәт төшү. [*Габденнасыйр:*] *Бу моңлы тавышың белән үзең кызлар күзе төшәрлек япь-яшь кеше булып китәр идең бит.* М. Гали. **Күз(ләр) түгәрәкләнү** — *к.* күз(ләр) шар(дай) булу. [*Ишмай:*] *„Чәчүне ике ат белән бергәләп алып барабызмы әллә, кордаш?" — дип башлаган иде, Халикъның күзләре түгәрәкләнде.* Ш. Камал. **Күз угы** — кемгә яки нәрсәгә дә булса төбәлгән күз карашы. *Татар да, безнең күз укларын хис итеп булырга кирәк, күзләрен газетадан алып, әүвәл кызга, аннан соң миңа карап куйды.* Ф. Әмирхан. **Күз(ләр) уйнау** — 1) *к.* күз(ләр) ялтырау; 2) нәрсәне дә булса бик нык теләү, нәрсәгә дә булса кызыгу (*к.* күз кызу). *Акча булганның кулы уйный, булмаганның күзе уйный.* Мәкаль. **Күз(ләр) ут булу** — көчле теләк, хис чагылышы буларак, күзләр бик нык ялтырый башлау. [*Дни:*] *„Улыма бер чибәр генә, юаш кына кызны димләп, чыгарып бирә аласың икән, менә шушы яулыкны сиңа һич тә кызганмый бүләк итәчәкбез", — диде. Апаның күзләре ут булды.* А. Шамов. **Күз(ләр) ут кебек (шикелле) яну, күз(ләр) уттай яну** — көчле теләк, хис һ. б. ш. ны белдереп, күзләр бик нык ялтырау. *Валлаһи, гашыйк булгансың, Күзләрең уттай яна.* М. Җәлил. **Күз(ләр) чагылу** — 1) күзләрне тутырып ачып карап булмау (кояштан, көчле яктылыктан һ. б.). *Кояш бүген ап-тык юмартланган, Күз чагыла көчле яктыда.* М. Гафури; 2) нинди дә булса өр-яңа яки матурлык ягыннан аерылып торган әйбер турында. [*Әгъзам:*] *Мантоларга гына кара син безнең. Күзең чагылыр.* Р. Ишморат. **Күз чамасы белән** — күз белән чамалап, күз белән билгеләп. **Күз(ләр) чекрәю** — *к.* күз акаю. *Үзе тегесен-монысын сөйләгән арада, уң күзе чекрәеп торса да, сулы юри шулай йомылган булып, җыен тиешсез урыннарны капшый кебек.* Г. Бәширов. **Күз чыга язу** — кемне яки нәрсәне дә булса бик озак көтү яки эзләү турында. [*Ирбулат:*] *Болай да Сабир абый справкасын эзләп күзем чыга язды.* Р. Ишморат. **Күз(ләр) шар(дай) булу, шарланып китү** — куркудан, гаҗәпләнүдән, көчле дулкынланудан һ. б. күзләр зур итеп ачылу. *Мондый сүзне ишеткәч, Баһаветдин агайның күзләре шардай булды.* Н. Фәттах. *Моны күргәч, Ибраһимның күзләре шарланып китә.* Г. Гобәй. **Күз эленү** — 1) йоклыйсы килү, йокы басу. *Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.* Г. Тукай; 2) караңгылану, караңгы төшү. **Күз явын алу** — нинди дә булса бик матур, үзенең матурлыгы белән аерылып торган предмет турында (күбрәк иң югары бәя бирү мәгънәсендә кулланыла). *Әйләнәмдә, күзнең явын алып, Зәңгәр гөлләр гөрләп үсәләр.* Ә. Ерикәй. **Күз явын алырлык** — бик матур, бик шәп.

Туй бүләге итеп --- Нәсимәгә кырык тиенгә күз явыңны алырлык --- француз яулык алып бирде. Ш. Камал. **Күз(ләр) ялтырау** — нинди дә булса хисне, хәлне һ. б. белдереп, күзләрнең үзенә бертөрле ялтыравы турында. *Май ашаган мәче кебек, Ялтырыйдыр күзләре.* Җыр. **Күз яну** — 1) нинди дә булса хисне белдереп, күзләр ялтырау. *Аның күзләре шаянланып яна иде.* А. Шамов; 2) зур теләк барлыкка килү, теләк уяну; кызыгу, теләү. *Закир нәрсә күрсә— шуңа кызыга, нәрсә күрсә — шуңа күзе яна.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Күз яше аралаш (катыш)** — күзгә яшьләр тулып, елап; елау катыш. *Ләкин әлекке заманнардагы кебек күз яше катыш шатлык бер дә булмады.* Г. Ибраһимов. *Сәгыйдә (күз яше аралаш): Рәхмәт, Сөләйман абый, — диде.* Һ. Такташ. **Күз яше (яшьләре) төшү (тоту)** — хорафат карашлар буенча: кемнең дә булса берәр кешене каргап елавы аркасында, ул кешегә начарлык, бәла, бәхетсезлек килү. *Кемгә генә төшәр икән егълаган күз яшемез.* Бәет. [*Мөрит:*] *Шәһәрдәге бар этләрне җыеп бер атауга илтеп ташлаганнар. Шуннан соң этләрнең күз яшьләре тотып, шәһәрдә халык кырыла башлаган.* Г. Камал. **Күз яше түгү** — елау, күз яше белән елау. [*Зәйнәп*] *Һәр вакытта күз яшьләрен түгә иде.* М. Гафури. **Күз яшенә буылу (тыгылу, төелү)** — елавын тыярга тырышып, сүз әйтә алмыйча тору; туктаусыз күз яшьләре агызу. *Ул, күз яшенә буылып, эчә торган чәен куйды.* Ак юл. *Җиргә целеп, Ул томанга нидер сөйли, Күз яшенә төелеп.* М. Җәлил. **Күз(ләр) яшьләнү** — күзгә яшь тулу; елау. *Иректән күзләр яшьләнде.* А. Әхмәт. **Күз яшьләре белән** — елап, елый-елый; күзенә яшь тулып. *Бөтен төнне ире турында, үткән гомере турында кайгылы уйлар белән, күз яше белән кичерде.* Г. Ибраһимов. **Күз(ләр) әлҗе-мөлҗе килү** — нинди дә булса физиологик яки психологик хәлдән күз аллары чуарлану, күз аллары караңгыланып-караңгыланып китү. *Көн шактый караңгыланды, эшләүчеләрнең күзләре дә әлҗе-мөлҗе килә башлады.* М. Гали. **Күз өстендәге каш** — бик кадерле яки кадерле булып саналган кеше турында. [*Хәрниса:*] *Гарифуллабыз, --- күз өстендәге каштай, карап торган бер шәп егетебез.* А. Расих. **Күз үлчәве (күреме) белән** — *к.* күз чамасы белән. [*Алтын*] *бит күз үлчәве белән казанга салына торган бәрәңге түгел.* Ш. Камал. *Мондагы тире җыючы да, тисә—тиенгә, тимәсә—ботакка дигәндәй, күз күреме белән генә кабул итә.* Соц. Тат. **Күз үлчәме (үлчәве)** — нинди дә булса озынлыкны, зурлыкны һ. б. приборсыз гына билгеләү, күз белән генә чамалау. **Күз җитмәслек** — күреп булмаслык, күз күреме җитмәслек. *Ярларыннан чыгып, сөзәк җирләргә, болыннарга җәелгән сазлык төсле, чигенә күз җитмәслек хәлгә килде.* К. Нәҗми. **Күз җитү** — 1) алдан күрә алу, алдан белү; белеп җиткерү. — *Мирзаның күзе җитмәгән, акылы ирешмәгән, кулы тимәгән кабахәтлекләрнең барысы Иргали кулы белән эшләнә.* Ф. Бурнаш; 2) ышану, ышанып җитү. [*Аксаби:*] *Аның әнисәне тәрбияләп үстерә алуына күзем җитми.* З. Бәширн. **Күзгә ак-кара күренмәү** — 1) бернәрсәгә дә игътибар итмәү. [*Мөгълифә:*] *Бары тик аңар матур хатын гына булсын, аннан соң ничә күзенә ак-кара күренми.* Г. Камал; 2) начар белән яхшыны аермау, бернәрсә дә аңламау. [*Әпипәнең*] *күзенә ак-кара күренми, --- әллә нинди бер нәмәрсәгә ияреп читкә китәргә йөри.* Г. Бәширов. **Күзгә ак төшү** — ялкынсынудан яки зарарланудан күзнең мөгез катлавында аксыл тап барлыкка килү. *Бер күзенә ак төшкән куркыныч кыяфәтле карчык кем икәнлегемне --- сорашканнан соң гына мине ишек алдына кертте.* Ф. Әмирхан. **Күзгә бәрелү (ташлану)** — 1) күренү, күзгә күренү; игътибарны үзенә тарту. *Уйсулыкта үскән бодайлар арасыннан чыгып килгән Мәрдәнша бабайның башлап көрәк кадәр ак сакалы күзгә бәрелде.* Г. Гобәй. *Алар, иртәдән үк бөтен даланы карап йөреп, күзгә бәрелерлек нәрсә тапмадылар.* Ш. Усманов. *Күзеннән түбән, сул битендә төзәлгән бер җәрәхәт әзе дә бер карашта үк күзгә ташлана иде.* Ш. Камал; 2) ачык сизелү, беленү. *Соңгы класста укыганда бу хәл аеруча күзгә бәрелә башлады.* М. Әмир. [*Миронов:*] *Бигрәк тә яшь кадрларыгызның үсүе күзгә ташлана.* Р. Ишморат. **Күзгә бәреп тору** — ачык сизелү, ачык күренү. *Бу җырда да шундый үк каршылык күзгә бәреп тора.* М. Җәлил. **Күзгә бәреп (әйтү, сөйләү)** — ачыктан-ачык, турыдантуры; тартынмыйча. **Күзгә йокы кермәү** — йоклап булмау, йоклый алмау. [*Айдар:*] *Пиджакны аска җәеп ятып карыйм, күзгә йокы керми.* Ф. Хөсни. **Күзгә карап (ялганлау, алдау, тану)** — оялмыйча, тартынмыйча, курыкмыйча; каушап калмыйча. [*Зәмзәмбану:*] *Күзгә карап тана бит.* Т. Гыйззәт. [*Кунаклар:*] *Күзгә карап алдалыйсың.* А. Алиш. **Күзгә карап җан сату** — ачыктан-ачык алдау, алдалау; хәрәмләшү. [*Рамай:*] *Их, Сабир абзый, күзгә карап җан сатучылар дип әйтәләр иде сезне, дөрес икән.* Т. Гыйззәт. **Күзгә каратып тоту** — кемне дә булса үзенә каратып тоту, буйсындырып тоту. **Күзгә керерлек булып, күзгә керердәй булып** — бик нык текәлеп, йотылып карау. [*Мөхип әби:*] *„Маржа кызының күзенә керерлек булып бара бит“, — дип, бармагы белән ишарә итеп, Закирны күрсәтте.* Ф. Әмирхан. [*Паларусов*], *ничектер, Садыйк турында гаҗәп бер нечкәлек белән, [Нәгыймәнең] күзенә керердәй булып, җавап көтә.* Г. Ибраһимов. **Күзгә кырып салырга (салырлык)** — аз гына да; бөтенләй. [*Кәрим:*] *Күзегезгә кырып салырга бер тиен бакыр да бирмим.* Г. Камал. [*Нәсимә:*] *Күзгә кырып салырлык он азыгы юк.* А. Расих. **Күзгә көл сибу** — *к.* күзгә төтен җибәрү. [*Шүрәле:*] *Син, егет, күзгә көл сибәргә яратасың кебек.* Д. Аппакова. **Күзгә көя булу** — берәр кешенең яки берәр нәрсәнең күңелгә начар тәэсир итүе турында.— *Күзгә көя булып йөрмәгез! — диде Салтыков.* Г. Минский. **Күзгә күз(не) кую** — кара-каршы утыру. [*Зөһрә:*] *Күзгә күзем куеп, төн утырып Барлык серләремне сөйләрмен.* Ф. Бурнаш. **Күзгә күренү** — 1) кем яки нәрсә дә булса күренү; кемне яки нәрсәне дә булса күрү, очрату.— *Урамга чыгарга, кеше күзенә күренергә оят.* А. Шамов; 2) сизелү, беленү. *Аның нәтиҗәсе тиздән күзгә дә күренә башлады.* Г. Бәширов. *Гимназиядә татар кызлары күзгә күренер дәрәҗәдә күбәеп бараллар.* Ф. Әмирхан; 3) басылып чыгу, дөнья күрү (басма әйберләр турында). *Ошбу көннәрдә китапчылык галәмендә ике гүзәл әсәр күзгә күренде.* Г. Камал. **Күзгә текәлү** — текәлеп карау, күзгә карау. [*Герасимов:*] *Разин нинди эшкә дип сезгә алты йөз сум акча бирде? — диде дә [Булатның] күзенә текәлде.* Г. Ибраһимов. **Күзгә терәп (сөйләү, әйтү һ. б.)** — *к.* күзгә бәреп (әйтү, сөйләү). [*Йөзлебикә*] *Сәйфинең --- эчеп йөрүләрен күзенә терәп сөйләп китте.* Г. Бәширов. *Бу юлы, димәк, батырлар табылган, Маликның күзенә терәп әйткәннәр.* И. Гази. **Күзгә терәү сугу** — бик авыр, кыен хәлгә калдыру. **Күзгә төртелү** — *к.* күзгә бәрелү (ташлану). *Шагыйрьнең бу хактагы фикерләренең дә оригинальлеге, үткер куелышы, җитдилеге күзгә төртелеп торганын күрми китү мөмкин түгел.* Г. Нигъмәти. **Күзгә төртсәң күренмәс(лек)** — караңгылыкның иң югары дәрәҗәсе турында. *Төн. Күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Ләкин разведка кешеләренең моңа исләре китмәде.* А. Әхмәт. **Күзгә төтен җибәрү** — алдау, ялганлау. [*Мирсәет:*] *Син безнең күзгә төтен җибәрергә азап-*

ланма. --- Бернинди өянәк тә, тез сызлау да юк синдә. Р. Ишморат. **Күзгә чалыну (чагылу)** — 1) күренү. *Караңгыда ниндидер ике шәүлә күзгә чалыныпкитте.* А. Шамов. *Пыяла савытка утыртылган кыпкызыл мәк чәчәкләре белән янәшә хәрби киемдәге бер хатын-кыз портреты күзенә чагылды.* Г. Бәширов; 2) сизелү, беленү. *Шулай ук М. Гафуриның хаклык, тигезлек идеяләрен конкрет көрәштән тыш, абстракт төстә куюы да күзгә чалына.* М. Җәлил. **Күзгә эләгү** — күренү. *Абыстай --- [Җәләлне], исерек булып, халык күзенә генә эләкмәсә ярар иде инде дип, елап-елап, төн буена башын мендәргә куймый чыкты.* Г. Ибраһимов. **Күзгә эләрлек** — игътибарга алырлык, игътибар итәрлек; кызыксынырлык. [*Фәтхулла:*] *Шулкадәр күп китап арасында, мәсәлән, бер күзгә эләрлеге юк икән.* Ф. Әмирхан. **Күзгә яше терәлү** — елау дәрәҗәсенә җитү, елап җибәрерлек хәлдә булу. [*Җамалый агайның*] *күзләренә яшьләр терәлде.* Һ. Такташ. **Күздә тоту** — 1) исәп тоту, исәп итү; берәр төрле исәп, максат белән эш итү; максат итеп кую. *Н. Исәнбәт бу вакыйганы сатира планында чишүне күздә тоткан.* М. Җәлил. *Айсылуның күздә тоткан кешесе — Тимергали карт шушы иде инде.* Г. Бәширов; 2) игътибарга алу, исәпкә алу. *Бүгенгенең чиксез ашкынуы, --- Алгы көрәшләрне күздә тотып, Кызулатты корыч адымын.* Һ. Такташ. **Күздә ут уйнау (кабыну, яну), күз(ләр)е ут уйнау** — тирән кичерешләрне, хисләрне чагылдырып, күзләр бик ныклы ялтырау. *Кызның күзләрендә утлар кабынды.* К. Тинчурин. [*Тимеркәй*] *каты басып, йөгереп килеп керә, шатлыктан күзләрендә ут яна.* Г. Ибраһимов. **Күздә чүп булып тору** — кемгә дә булса комачаулау, кемне дә булса борчу. [*Хәйретдин:*] *Китсеннәр алар, күздә чүп булып тормасыннар.* Х. Кәрим. **Күздән кичерү (үткәрү)** — 1) карап чыгу, җентекләп карау. *Хәйдәр аның җемелдек алкаларыннан алып үлән сүленә буялган яшел кулларына --- хәтле — бөтен буен-сынын күзеннән кичерде.* Г. Бәширов. *Хәят, гадәтенчә, комод тартмаларын актарып ташлады да йөз кат күргән нәрсәләрен йөз дә беренче кат күздән үткәреп чыкмакчы булды.* Ф. Әмирхан; 2) хәтердә искә төшерү. *Җиһанша хәзрәтнең кереп утырганнан башлап чыгып киткәнгә кадәр булган хәлләрене берәм-берәм күздән кичерде.* З. Һади. **Күздән төшерү** — берәр кешенең кем каршында булса да абруен төшерү, яхшы атын (исемен) юкка чыгару. [*Шөҗаг:*] *Аны юлдан яздырмыйча, аны байның күзеннән төшермичә туктамам.* Г. Камал. **Күздән төшү** — 1) дәрәҗә, абруй төшү, югалу. *Күздән төшкән телдән дә төшәр.* Мәкаль. *Шуннан соң Тәһирҗан хәлфә тәмам күздән төште.* З. Һади; 2) игътибардан читтә калу; онытылу. [*Утерелгән кешене*] *күму эшләре шунда ук онытылып күздән төште.* М. Гафури. **Күздән (күзгә) ут күренү** — күз алдында очкыннар чәчрәгән кебек булу (бик каты бәрелү-сугылудан һ. б.). *Өстәвенә, яңагына чапты [ир] берне чалт итеп, Күзенә мескен хатынның ут күренде ялт итеп.* М. Гафури. **Күздән югалу (юк булу)** — күренми башлау, юкка чыгу (мәсәлән, берәр җирдән ераклаша барып). *Поезд борыла-сырыла барды-барды да урман эченә кереп күздән югалды.* Г. Гобәй. *Газинур, читән аша сикереп, шунда ук күздән юк булды.* Г. Әпсәләмов. **Күздән ычкындырмау** — даими рәвештә күзәтеп тору, күзәтү астында тоту. [*Гриша:*] *Мин аларны күздән ычкындырмый карап торам.* Ш. Усманов. **Күздән язу** — күзәтеп, карап торган предметны күрми башлау, югалту (ераклашу, читкә китү һ. б. аркасында). **Күзе атылып чыгарга тора** — куркудан күзләрне бик зур итеп ачу турында. *Шулай да [Мәрьямнең] куркуыннан йөрәгеярылырга бара, күзләре атылып чыгарга тора шикелле иде.* Г. Ибраһимов. **Күзе ачык** — грамоталы, аңлы, белемле. *— Их, күрсәгез иде, бөтенләй икенче халык, күзе ачык халык.* Ак юл. **Күз(ләр)е дә йөз(ләр)е** — сүз барган кешеләр алдында, ачыктан-ачык. **Күзе каты** — хорафат карашлар буенча: бәхетсезлек, авыру (чир) китерә торган, янәсе, магик көчкә ия күзләр турында әйтелә. *Күзең каты икән, Җәмилә, күз тидерә яздың.* Х. Садрый. **Күзе очлы** — күзе үткен; тиз күреп (аңлап, белеп) ала торган. [*Хәмдия:*] *Комсомолларның күзләре очлы аларның.* Р. Ишморат. **Күзе чыккан** — берәр эштә зур тәҗрибә туплаган, бик ныкостарган кеше турында.—[*Баһау*], *киңәш-табыш сорап, минем кебек колхоз эшендә күзе чыккан кешеләргә бармый.* А. Расих. **Күзе әйтеп тору** — нәрсә дә булса күз карашыннан беленү, сизелү; күздә чагылу. **Күзем (чәчрәп) чыксын** *гади с.* — сөйләгәннең дөреслегенә ышандыру өчен әйтелгән ант сүзе. — *Ялган булса, ике күзем чәчрәп чыксын.* Г. Бәширов. **Күземнән югал** *гади с.* — *к.* күземә күренмә(гез) (1 мәгъ.). [*Мәфтуха:*] *Дәй әнинең ачуы килде. --- Бар, күземнән югал, --- дип орышты-орышты да куып чыгарды.* А. Әхмәт. **Күземә күренмә(гез)** — 1) „чыгып кит, күз алдында торма“ мәгънәсендә кулланыла. [*Җамал әби:*] *Хәзер үк кире илт, күземә күренмә, моннан соң бер кошның да йомыркасына үрелмә!* А. Алиш. [*Камали:*] *Нәрсәгә тавыш күтәрәсез минем алдымда? --- Барыгыз, күземә күренмәгез!* Ф. Бурнаш; 2) „килмә(гез), килеп йөрмә(гез)“ мәгънәсен белдерә. [*Җәләл:*] *Дәгәр дә сүземне тыңламасаң, мине ата дип белмә, күземә күренмә, йортыма аяк басма.* Г. Ибраһимов. **Күзен төшерү** — кемнең дә булса игътибарын җәлеп итү, игътибарын тарту. *Тавышны мәдрәсәдән тышка чыгару дигән сүз бу мәдрәсәгә полициянең күзен төшерү дигән сүз иде.* Ә. Фәйзи. **Күзеннән итү** — нәрсәне дә булса савыт тулганчы тутыру, мөлдерәмә итү. **Күзеннән ут уйнату (чәчү)** — тирән кичерешләрне, хисләрне чагылдырып, күзләрне бик ныклырату. *Кыз, кинәт селкенеп, Фәхригә борылды, күзеннән ут уйнатып, зәһәр белән җавап бирде.* Г. Ибраһимов. **Күзенә йотылу** — кемнең дә булса күзенә бик ныктекәлеп карау, күзне төбәү. *Гаепләнүчеләр прокурорның күзенә йотылдылар.* Г. Ибраһимов. **Күзең чыккан нәрсә** *шелт.* — *к.* күзең (тишелеп) чыккыры. [*Гөлҗиһан:*] *Бирермен, өшәгән авыз, сиңа йомышыңны. Күзең чыккан нәрсә!* Г. Камал. **Күзең чыкканмы (әллә)** *гади с. шелт.* — „күрмисеңме?“, „күзең юкмы?“ мәгънәсен белдерә. *Ындыр сукканда хатыны катырак тәпәчләсә,* [*Гафият*], *хәзер ачуланып: „Күзең чыкканмы? Читкә чәчрәтәсең!“ — дип кычкыра иде.* И. Гази. **Күзең (тишелеп) чыккыры** *гади с. шелт.* — кемне дә булса орышканда, тиргәгәндә кулланыла. [*Мәликә:*] *Ялгыш, имеш, ялгыш! Күзең тишелеп чыккыры нәрсә!.. Болай булганда, бөтен нәрсәләрне ватып, кырып бетерерсең син.* А. Шамов. **Күзне акайту** *гади с.* — күзләрне зур итеп ачу (гаҗәпләнүдән, ачуланудан һ. б. ш.). *Ул кызарынды, үзем дә кызарындым. дни миңа күзен акайтып карады.* Ф. Әмирхан. **Күзне алу** — кемгә яки нәрсәгә дә булса караудан туктау. *Ялчы Йолкымбай кымыздан күзен алды, чөнки өметланү файдасыз иде.* Г. Ибраһимов. **Күзне ачу** — 1) уяну, йокыдан уяну. [*Карт*], *бишенче көне дигәндә, таң алдыннан, шабыр тиргә батып, күзен ачты.* Г. Бәширов; 2) кемгә дә булса берәр нәрсә турында дөреслекне мәгълүм итү (ачу), нәрсәнең дә булса чын асылын ачып салу. *Көтелмәгән кечкенә бер вакыйга Нургалинең күзен ачты.* Ә. Еники. **Күзне ачып йөрү** — карап, сакланып йөрү. [*Сафа:*] *Күзеңне ачыбрак йөрсәң, ярамас идемени!* А. Шамов. **Күзне гарешкә терәп** — аллага

сыгынып, аллага ялварып (кайбер вакытта күчмә мәгънәдә „бик нык өмет итеп“, „зур өмет белән“ дигән мәгънәне дә белдерә). [*Вахит*], *күкрәк кесәсенә тегеп куйган догалыкларны алып, күзләрен гарешкә терәп укый торган иде.* М. Гафури. **Күзне йокы алмау** — йоклый алмау. *Туры байталының абзарында керт-керт печән ашавын тыңлый-тыңлый,* [*Тимери*] *күп төннәрен, күзгә йокы алмыйча, уфылдап уздырды.* Г. Бәширов. **Күзне йокы басу** — бик нык йоклыйсы килү. *Карчыкның башы эшләми, күзен йокы баскан иде.* Г. Ибраһимов. **Күзне йомып йөрү** — игътибар итмәү, игътибарга алмау. [*Гарәфи абзый:*] *Агач та — шундый ук алтын. Без алтынның өстеннән таптап йөрибез, әмма берни күрмибез. Күзләрне йомып йөргәч, шулай була икән ул.* Г. Әпсәләмов. **Күзне калайландыру** — *к.* күз(ләр)не тозландыру. *Карчык, күзен калайландырып, тагын шул элекке сүзен сөйли башлады.* Г. Толымбай. **Күзне камаштыру** — *к.* күзне чагылдыру. *Аларның берсе, бер чактай вак кына ак төймәләр белән тезелгәне, чын сәдәп кебек елкылдап, Габдулланың күзләрен камаштыра.* Ә. Фәйзи. **Күзне кан басу (кан алу)** — бик каты ачудан, көчәнүдән һ. б. ш. кан күбрәк килү аркасында күз кызару. *Егорыч сүзен бетерер-бетермәс, күзләрен кан баскан подполковник, аягына баскан көйгә, йодрыклап өстәлгә сук*[*ты*]. М. Гали. *Йөрәгем яна ла... Күзем кан ала.* Ф. Бурнаш. **Күз(ләр)не кыздыру (кызыктыру)** — теләк уяту, теләк тудыру; күңелне үзенә тарту, җәлеп итү. *Хәлим мәктәптә кесәсеннән чыгарган саен балаларның күзләрен кыздыра торган бик матур авторучкасын иптәшенә сузды.* Г. Гобәй. **Күзне күзгә текәп (төбәп, терәп)** — бер-берсенә күзләрен төбәп, бер-берсенә карашып. *Бик озак торгач карашып, Күзне күзгә нык терәп, Әндәшә батыр утынчы: „Сиңа миннән ни кирәк?“* Г. Тукай. *Күзне күзгә терәп күпме торганбыздыр, берчакны бу, берни дә булмаган төсле, уен-көлке белән кушып әйтеп ташлый.* Ф. Хөсни. **Күзне майландырып карау** *гади с.* — күзләрдә нинди дә булса теләк, хис чагылу. *Закир аңа күзен майландырып кына куя.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Күз(ләр)не мөлдерәтеп (тутырып) карау** — күзләрне зур итеп ачып, текәлеп карау. *Галләм абзый, - - - күзләрен мөлдерәтеп, приставка карап калды.* М. Гафури. *Хәсән маңгаена төшкән чәчләре арасыннан күзләрен тутырып карады.* Ш. Усманов. **Күзне тегү** — *к.* күз(не) текәү. *Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә, Яшь һилял урнында — анда тулган айның яртысы.* Г. Тукай. *Фәтхулла хәзрәт Ишми ролен уйнаучы артистка күзен текте.* Ф. Әмирхан. **Күз(не) текәү** — 1) кемгә яки нәрсәгә дә булса туп-туры карау, күзләрне юнәлдерү, күз карашын юнәлдерү; текәлү. *Күзләрен бер ноктага текәп тавышсыз-тынсыз гына елаган карчык - - - яшенә буыла-буыла үксергә кереште.* А. Шамов; 2) өмет белән карау, ышанып карау. *Бөтен дөнья йөзе бу көннәрдә Күз текәгән Мәскәүгә табан.* М. Гафури. **Күзне терәү** — *к.* күз(не) текәү (1 мәгъ.). *Кергән минуттан башлап залның төньягындагы калкуга, кызыл постаулы өстәлгә, әгъзаларга, бигрәк тә зур буйлы, ябык йөзле рәис Биганов күзләрен терәде дә шуннан аерылмады.* Г. Ибраһимов. **Күз(ләр)не тозландыру** — нинди дә булса теләкне, тирән хисне белдереп, күзләрне киң итеп ачу, күзләрне ялтырату. *Бу сүзне ишеткәч, хәзрәтнең кәефе килде, - - - күзләрен тозландырып, бик каты тавыш белән - - - кычкырды.* Ф. Әмирхан. *Сәүдәгәрләр, файда сүзен ишеткәч, күзләрен тозландырдылар* Г. Гобәйдуллин. **Күзне тондыру** — нәрсә дә булса өмет итеп, нәрсәне дә булса теләп, күзләрне зур итеп ачу. *Идел буйларында кан әчәргә Дошман килә, күзен тондырып.* Ә. Ерикәй. **Күз(не) төбәү** — *к.* күз(не) текәү. *Ул ашыгып кулын кутәрде дә Зал өстенә күзен төбәде.* Һ. Такташ. **Күз(не) уйнату** — күзләрне ялтырата-ялтырата карау, кискен карашлар ташлап карау. *Малай, күзләрен уйнатып, кашларын җыерып, җикеренгәләп утыра башлады.* И. Гази. **Күзне чагылдыру** — 1) күзне тутырып ачып кararга комачаулау, күзгә начар тәэсир итү (көчле яктылык һ. б. турында). *Багананың як-ягында, күзне чагылдырып, кечкенә көзге кыйпылчыклары уйнаша.* Г. Бәширов. *Җир астында тапкан алтыннары күзне чагылдырып торалар.* М. Гали; 2) нинди дә булса матур, өр-яңа яисә яхшы яктан аерылып торган әйбер турында. *Бер дә тотылмаган, күзне чагылдырырлык ак яулык чыгарып, маңгаена тидергәләп алуга, тирә-юньгә бик нәфис, бик тәмле хушбуй исе җәелде.* Г. Гобәй. **Күзне чекрәйтеп карау** *гади с.* — күзләрне зур итеп ачып карау. *Д үзе узган-барганнарны күзләрен чекрәйтеп карап тора.* А. Шамов. **Күзне челәйтү** *гади с.* — нинди дә булса өмет яки теләк белән текәлеп карау, күзләрне тартынмыйча зур итеп ачып карау. *Мәүлиха түти Сәйфинең, олы башы белән, дпипәнең шәрә балтырларына шулай күзен челәйтеп торуын һич ошатмады.* Г. Бәширов. **Күзне шар итү** — кызыксынудан, гаҗәпләнүдән күзләрне бик зур итеп ачу. [*Курчак:*] *Күзегезне шар итеп, Юк вакытны бар итеп, Менә монда карагыз.* М. Җәлил. **Күзне яндыру** — кызыксыну уяту, көнләштерү. — *Кызларның күзен яндырып йөри бирәм әле диген?* М. Фәйзи. **Күзне яшьләндерү** — күзләрдән яшь чыгару, елау. [*Мәрьям*] *Вахитның уң белгеннән килеп тотты да, күзләрен яшьләндереп, абзыйсының йөзенә карады.* М. Гафури. **Күзнең бер чите белән карау** — *к.* күз кырые белән карау (күрү һ. б.). *Филимонов кәгазьне алды, сүзен һич туктатмастан, күзенең бер чите белән генә карады.* Г. Ибраһимов.

КҮ'ЗАЛЛАУ *ф.* 1. *махс.* Элек кичергән, баштан үткәргән нәрсәләрне аңда, хәтердә яңадан барлыкка китерү, күз алдына китерү. *Спецификлы булмаган тыныч сызлаучылар китереп чыгарган тойгылар предмет турында ялгыш күзаллау тудыра алмыйлар.* Анатомия.

2. Нәрсәне дә булса беркадәр аңлау, төшенү. *Әгәр дә Фәйзуллин иптәш шул ук хәлне музыка ижатында да күрә икән һәм шуны күзаллап, яңача җырлау турында сүз алып бара икән, ни гажәп?!* А. Әхмәдуллин.

КҮ'ЗАЛМАМ *и. ирк.* Кемгә дә булса иркәләп әйтелә торган, „җаным“, „бәгърем“, „сөеклем“ мәгънәсендәге мөрәҗәгать сүзе. [*Хатын:*] *Күзалмам, үзеңне саклый күр, сабыйларың өчен, - - - сине сагынып сөюче - - - иптәшең өчен саклый күр.* А. Шамов.

КҮЗ-БАШ: күз-баш алу — нинди дә булса бер хәлдән соң тормыш беркадәр җайлану, рәткә салыну турында.

◇ **Күзе-башы алакаю (күрмәү)** — күзенә ак-кара күренмәү, берәр нәрсәгә җитди игътибар итәрлек хәлдә булмау. [*Мәгъри:*] *Аларның да шул, сезнеке шикелле, күзе-башы алакайган бер асраулары бар.* Г. Камал. **Күзен-башын әйләндерү** — берәр кешене нинди дә булса юллар белән үзенә карату яисә берәр нәрсәгә җитди игътибар итә алмаслык хәлгә китерү турында.

КҮЗГӘ-БАШКА: күзгә-башка күренмәү — кем белән дә булса очрашмау, кемнең дә булса күренмәве, килмәве турында.

КҮЗГӘ-КҮЗ *рәв.* Икәүдән-икәү генә; башка кешеләр булмаганда, башкалар юк чакта. *Күзгә-күз очрашу.*

◇ **Күзгә-күз карашу (карау)** — кемнәрнең дә булса бер-беренә каравы, күзләрен бер-беренә текәп

торуы турында. *Ишмай белән Гөлбикә гажәпләнеп күзгә-күз караштылар.* Ш. Камал. **Күзгә-күз очрашу** — кара-каршы очрашу, икәүдән-икәү очрашу. *Дошман белән беренче тапкыр күзгә-күз очрашудан ул бер нәрсәне бик яхшы сизеп калды: каушамаска кирәк икән.* Ә. Еники.

КҮЗДӘЙ: күздәй итү (тутыру, тулу) — мөлдерәмә итеп тутыру, мөлдерәмә тулу. *Аңа ияргәннәр һәркайчан савытларын [җиләк белән] күздәй тутырып кайталар.* Г. Ибраһимов.

КҮЗЕГҮ *ф.* 1. Хорафат карашлар буенча: янәсе, берәр кеше карашының, күзенең магик тәэсире нәтиҗәсендә авыру, бәхетсезлек барлыкка килү.

2. *күч. ирон.* Мактаганнан соң нәрсәнең дә булса начарлануы турында әйтелә.

КҮЗЕКТЕРҮ *ф.* 1. Хорафат карашлар буенча: янәсе, күзнең, карашның магик тәэсире белән авыру (чир), бәхетсезлек барлыкка китерү, зарар итү.

2. *күч. ирон.* Берәр нәрсәнең мактаганнан соң начарлануы турында.

КҮЗЕЛДЕРЕК *и. диал. к.* күзлек (2 мәгъ.).

КҮЗИКМӘК *и. махс.* 1. Төче камырдан юка итеп җәеп, табада пешерелгән ашамлык.

2. *к.* кыстыбый (1 мәгъ.).

КҮЗ-КОЛАК: күз-колак булу — кемне яки нәрсәне дә булса күзәтү астында тоту, кемнең яки нәрсәнең дә булса эш-хәрәкәтләрен күзәтеп, тикшереп тору. [*Шәйхезаман:*] *Шулай, әфәнделәр, мин кайтканчы мәдрәсәгә күз-колак булуны, шәкертләр өстеннән карап торуны сезгә тапшырам.* Т. Гыйззәт. *Хәзинәдә барын пешерермен, бала-чагаларга да күз-колак булып торырмын.* С. Рафиков.

КҮЗ-КҮЗ *с.* Түгәрәк-түгәрәк, күз кебек түгәрәк (берәр нәрсәдә булган бизәк һ. б. турында). [*Тависның*] *койрыгындагы күз-күз түгәрәк бизәкләре бик оста сурәтче кулы белән ясап куйган төсле.* Ә. Фәйзи.

КҮЗЛЕ: күзле бүкән (багана) *гади с.* — эшкә катнашмыйча карап торган яисә эшкә күңел бирмичә эшләгән кеше турында. *Болай, бер сүз әйтми, күзле бүкән булып тору тагы килешми иде.* Ан. [*Гаяз:*] *Димәк, без алдыбызда торган бурычлар турында сөйләшкәндә, ул бурычларны ничек итеп тормышка ашыру планнарын сызганда, син күзле бүкән булып утырдың?* М. Әмир. **Күзле сукыр** — нәрсәне дә булса аңламаган, төшенмәгән яисә надан кеше турында. *— Д без, ди* [*Миңлевәли*], *муллалар артыннан күзле сукыр булып бара алмыйбыз инде, ди.* М. Фәйзи.

КҮЗЛЕ-БАШЛЫ: күзле-башлы булу — өйләнү, гаилә кору; хатынлы булу яисә кияүгә чыгу, ирле булу. [*Шәмсетдин*], *шул хатынга йортка кереп бер атна дигәндә, йортлы-җирле, күзле-башлы булып алды.* Г. Бәширов. **Күзле-башлы итү** — өйләндерү, хатынлы итү; кияүгә бирү, ирле итү. [*Днисе:*] *Бердәнбер баламны үз исәнемдә күзле-башлы итеп калдырасым килә.* Г. Бәширов.

КҮЗЛЕК *и.* 1. Күзнең күрү сәләтендә кимчелекләр булганда яисә күзне көчле яктылыктан, зарарланудан саклау өчен күзгә киелә торган ике пыяладан гыйбарәт оптик әсбап. *Күзлеген борын очына гына элгән Карп Васильевич картларча ашыкмыйча, әкрен генә атлый.* Г. Әпсәләмов. *Нәфисә* [*ашлык сукканда*] *бөтен йөзен каплап торган зур күзлеге аша әле бер якка, әле икенче якка карап ала.* Г. Бәширов.

2. Өркәк атка читкә кararга комачаулау өчен йөгәндә махсус эшләнгән каплавыч. *Йөгән күзлеге.*

3. *күч.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса билгеле бер караш, унай яки тискәре мөнәсәбәт (күбрәк чыгыш һәм сирәгрәк урын-вакыт килешендә кулланыла). *Алар безгә, милләт, тел аермалыгына карамый, сыйнфый күзлектән карап интернациональ әдәбият тудырырга социаль заказ бирделәр.* Һ. Такташ. *Бөтен уен шушы метод күзлегеннән торып җентекләп эшләнгән.* М. Җәлил.

4. *диал.* Умарта оясын караганда умартачының битен кортлар чагудан саклау өчен юка мамык тукымадан, тюльдән яисә нечкә тимерчыбыктан челтәрләп ясалган җайланма, битлек. [*Умарта бакчасындагы*] *кабыктан ясалган куыш, аның тирәсендәге коры умарталар, читлек, күзлек, тубал кебек нәрсәләргә без ияләшеп беткән идек.* М. Гафури.

КҮЗЛЕКЛЕ *с.* Күзлек кигән, күзлек киеп йөри торган. *Бу сүзне дә күзлекле кеше „аңлашыла" дигән бер сүз белән җиңел генә уздырып җибәрде.* К. Нәҗми.

Күзлекле елан *зоол.* — кобралар төркеменнән муенында күзлек сыман табы булган бик агулы елан. *Җәгъфәр, батырчылык итеп, бу, күзлекле еландай, үзен гипнозлап йотарга җыенган хатыннан китәчәк иде.* А. Расих.

КҮЗЛУТ *и.* Иренчәчәклеләр семьялыгыннан сабагы дүрт кырлы, шәмәхә кызыл чәчәкле берьеллык чүп үлән. *Һәммәсенең дә исе, төсе, исеме бар аларның. --- Менә бу кырыйдагылары күзлут дип атала.* А. Гыйләҗев. *Зәңгәр чәчәк, эт какысы, кыр тормасы, билчән, күзлут --- һәм башка шундый чүп үләннәр хәзер агротехникадан артта калган хуҗалыкларда гына очрыйлар.* Умартачылык.

КҮЗЛӘВЕК *и. сөйл.* Бозда тишелгән урын; астагы суы күренеп торган тишек. *Тәрәзә бозын өреп, шул күзләвектән мин аның ничек бездән чыгуын күрдем.* Н. Исәнбәт.

КҮЗЛӘШТЕРҮ *ф.* Ике кеше үзләре күргән, ишеткән, белгән нәрсә турында бер-берсенә туры килми торган фикер әйткән вакытта, хакыйкатьне билгеләү өчен, аларны бер-берсе белән очраштыру, очраштырып сөйләтү; кара-каршы китерү.

КҮЗЛӘҮ I *ф.* 1. *сөйл.* Кемне яки нәрсәне дә булса җентекләп карау, күзәтү; күзәтеп тикшерү. *Хәлим сәламәтлянә башлады. Ул хәзер күршеләренә карый, бүлмәдәге вакыйгаларны күзләп ята.* И. Гази. *Килгән юлы белән тагын китеп барганлыгын күргәч,* [*ул*], *берничә адым алга чыгып, тегене күзләде.* Ш. Камал.

2. Нәрсәне дә булса кайгырту, берәр нәрсәне булдырырга тырышу. *Үз файдасын гына күзләп, эшчене эткә дә хисап кылмаган байның тәлинкәсен ялаучы доверенный бу эшне сизгәч тә Искәндәр байга җиткерде.* Ш. Мөхәммәдев.

3. Карап сайлау, үзенә ошаганны эзләү. *Егетләр безне күзлиләр Язгы сабан туенда.* Җыр. [*Сәгыйтов:*] *Бар иде минем дә, кызлар күзләп, кача-поса йөргән чаклар.* С. Рафиков.

КҮЗЛӘҮ II *ф. махс.* Кыргый җимеш агачына культуралы җимеш агачы бөресен ялгау.

КҮЗЛӘҮ III *ф. иск., диал.* 1. Төзәү. *Шулвакыт Кара Мәргән аңар күзләп атып та җибәрде.* Ак юл.

2. *диал.* Саплау. *Инә күзләү.*

КҮЗМӘ-КҮЗ *рәв. сөйл. к.* күзгә-күз. — *Кирәк булса, мин яшьләрнең үзләре белән күзмә-күз һәм ныграк сөйләшермен.* Ш. Камал.

◇ **Күзмә-күз карашу** — *к.* күзгә-күз карашу (карау). *Көн буена икәү кара-каршы, күзмә-күз карашып утыралар да икән, берсе уйнап, берсе җырлап гомер үткәрәләр --- икән.* Г. Ибраһимов.

КҮЗСЕЗ *с. сөйл.* Сукыр, күзе күрми торган, күрү сәләтен югалган. [*Г. Камалның*] *инсценировкаларыннан бары тик „Күзсез мастерлар" дигән әсәр генә басылган.* М. Гали.

Күзсез калу — сукыраю, сукырга әйләнү, күрү сәләтен югалту. — *Син ач килеш йөргән чакта, синең өчен елый-елый күзсез калучы, синең бәхетең өчен*

җир өстендә тәмуг газаплары алучы ул кем иде? Һ. Такташ.

КҮЗСЕНДЕРҮ *ф. к.* күзектерү. [*Нәфига әби:*] *Алма кебек балаларыгызны, җыен яман күзләргә күрсәтеп, күзсендереп бетерәсез.* М. Әмир.

КҮЗСЕНҮ *ф. к.* күзегү. *Күзләрең күзсенмәсен, мин сокланып туймыйм карап.* Ш. Бабич.

КҮЗЧӘ *и.* 1. Җимеш агачына ялгау өчен культуралы җимеш агачыннан кисеп алынган бөре, чыбыкча. *Культуралы алмагач үстерү өчен чәчкеннәрне ялгыйлар. Күбрәк күзчәләр, ягъни бөреләр ялгыйлар.* Ботаника.

2. Бәрәңге бөресе, бәрәңге өстендәге бөре. *Бүлбе бөреләреннән (күзчәләрдән) кыска яшел бәбәкләр үсеп чыга.* Ботаника.

КҮЗӘЛӘМӘ: күзәләмә итү *диал.— к.* күзеннән итү („күз“ сүзендә).

КҮЗӘЛӘҮ *ф. диал. к.* күзләү I. *Җомагыл тәрәзә төбенә утырган да үзенең нуры сүнеп бара торган коңгыр күзе белән әледән-әле Гөлсемне күзәли.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

КҮЗӘНӘ *и.* Чәчкечтә орлыкларны рәт-рәт итеп чәчеп бару өчен хезмәт итә торган җайланма. [*Сапай карт:*] *Машина өчен орлыкны аеруча нык иләргә кирәк, менә мин карап бардым, машинаның күзәнәсенә бер солы эләккән, аны чәчүче күрми.* М. Җәлил.

КҮЗӘНӘК *и.* 1. Нинди дә булса предметта яки предметның эчендә булган вак куык, кечкенә бушлык. *Менә аның тирән куныч лы күн калошлары күзәнәкле бозга баттылар.* К. Нәҗми. || Икмәк пешергәндә эчендә барлыкка килгән кечкенә куык, бушлык. *Шүрлектән күпереп пешкән ярты ипи үзенең эрелеваклы күзәнәкләре белән карап утыра иде.* Г. Гобәй.

2. Кәрәздәге тишек, оячык, күзчек (бер-беренә охшаган бу оячыклар кәрәздә система тәшкил итәләр). *Умартага куелган кәрәзләргә бал тутырылып, кортлар кәрәзнең югарыгы өлешендәге күзәнәкләрен печатьли башлау белән, аларны суырту өчен алырга кирәк.* Умартачылык. *Күзәнәкләрдәге сыек бал, суыртту көченә каршы тора алмыйча, машина стенасына сибәли.* А. Алиш.

3. *к.* күз (7 мәгъ.). *Челтәр күзәнәге.* □ *Менә бу йомшак перчаткаларның матур күзәнәкләренә яшь киленнәрнең нинди генә теләкләре бәйләнмәгән.* Г. Бәширов. *Күлмәк бәйлим бүләккә, Батыр сугышчы өчен, Салып һәр күзәнәккә Йөрәгемнең җылысын.* Ә. Исхак.

4. Бәрәңгенең орлык өчен кисеп алынган, күзчәләре булган өлеше яки күзе үзе. *Фермага барышлый, урау булса да, бәрәңге күзәнәге кисүчеләр янына туктадык.* Л. Ихсанова.

5. *биол.* Терек организм төзелешенең протоплазмадан, ядродан (төштән) һәм тышчадан гыйбарәт иң гади берәмлеге. *Һәрбер терек күзәнәккә тереклекнең барлык төп күренешләре: матдәләр алмашы, тыныч сызланучанлык, үсү һәм үрчү хас.* Биология. *Күзәнәкнең тышчасы тыгызланган протоплазма катлавыннан тора.* Анатомия.

6. *тех.* Механизмда нинди дә булса деталь куела торган тишек, уем. *Комбайн сәнәге күзәнәгеннән атылып чыгу.*

КҮЗӘНӘКАРА *с.* Тукыманың күзәнәкләре арасында булган, күзәнәкләре арасына урнашкан. *Күзәнәкара матдә.*

КҮЗӘНӘКЛЕ: күзәнәкле бетон *махс.*— эчендә күзәнәкләр (1 мәгъ.) ясалган махсус бетон. *Күзәнәкле бетон заводы.*

КҮЗӘНӘКЛЕЛӘР *и. махс.* Күзәнәк төзелешле организмнар. *Алар төшсез һәм тышчасыз булып, гади аксым төерчекләреннән торганнар. Болар күзәнәкләргә кадәр организмнар булганнар.* Биология.

КҮЗӘНӘКЧЕЛ *с.* Күзәнәкләрдән (5 мәгъ.) торган, күзәнәкләрдән гыйбарәт. *Үсемлек ничек үсә соң? Моны үсемлекләрнең күзәнәкчел төзелешен ачканнан соң гына аңлату мөмкин булды.* Ботаника.

КҮЗӘТЕЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* күзәтү (1—6 мәгъ.). *Ләкин аның төбендә күзәтелгән нәтиҗә тагын да кыйммәтлерәк.* Ш. Камал.

2. Күренү, беленү, сизелү. *Нинди дә булса конкрет тарихи фактның чагылуы күзәтелми.* М. Җәлил. || Булу, булып тору. *Бу хәл анда еш күзәтелә.*

КҮЗӘТЕШ *и. кит.* Берәр нәрсәне игътибар белән карау, тикшерү, күзәтү. *Урыны белән бу сагышлы хыялга чолганган күзәтешләр, үткенләшә төшеп, социаль протест дәрәҗәсенә дә күтәрелә ләр.* Г. Нигъмәти.

КҮЗӘТЧЕ *и.* 1. Дошман турында мәгълүматлар җыю өчен җибәрелгән хәрби хезмәткәр, разведкага җибәрелгән хәрби хезмәткәр, разведкачы. *Күзәтчеләрдән алынган хәбәрләргә караганда, Капитоновка станицасында ике меңләп казак җыелган.* Ш. Усманов. || Дошманны, ул урнашкан җирне ерактан күз белән генә күзәтүче хәрби хезмәткәр. *Полк командиры штабка килеп керү белән үк,* [ул] *аңа чиркәү башындагы күзәтче китергән мәгълүмат турында сөйләргә тотынды.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Разведка белән шөгыльләнүче, разведкага җибәрелгән, разведкачы. *Күзәтче отряд дошманның Капшап кайткач йөрген, Барып күккә очырабыз Аның соңгы терген.* М. Җәлил.

2. Кемне яки нәрсәне дә булса күзәтү, тикшерү, сынау белән шөгыльләнүче кеше. [*„Безнең шәһәрнең серләре“ әсәрендәге*] *Себер бае тибын уңай тип дип аңларга һич ярамый. Ул читтән килгән бер күзәтче сыйфатында йөрүче бер кеше генә.* М. Гали. *Югары уңыш күзәтчеләренең бурычлары турында агрономнан соң ячейка секретаре сөйләп китте.* А. Алиш.

КҮЗӘТЧЕЛЕК *и.* 1. Кемне яки нәрсәне дә булса күзәтү, тикшерү, сынау эше. *Теле белән генә кызыксына, күзләре күзәтчелектә түгел.* Ш. Маннур.

2. Күзәтү-тикшерү эше белән шөгыльләнүче орган. *Санитария күзәтчелеге. Янгын күзәтчелеге.*

3. Берәр эшнең башкарылуын күзәтү, аның турында кайгырту; надзор эше алып бару. *Хәзер аның проекты буенча һәм аның күзәтчелегендә шәһәрдә берничә магазин яңадан төзелә.* Соц. Тат.

4. Дошман турында мәгълүматлар җыю максаты белән хәрби подразделение, группа һ. б. тарафыннан алып барылган күзәтү-тикшерү эше.— *Үзебез һаман күзәтчелек эшен алып барабыз.* Ә. Айдар.

КҮЗӘТҮ *ф.* 1. Кемне яки нәрсәне дә булса, яисә берәр эш-хәрәкәтне җентекләп карау, күздән кичерү. *Габдулла урамны һәм кешеләрне күзәтергә тотынды.* Ә. Фәйзи. *Кулын каш өстенә куйган килеш, сугышка ташланачак солдатларны күзәткән командир шикелле, яшь сөрүчеләрне күзәтә иде.* Г. Гобәй. [*Без*], *--- урман артыннан кызыл айның килеп чыгуын, йолдызларның берәм-берәм кабынуын күзәтеп, тып-тын утыра идек.* И. Гази. *Мин аларның хәрәкәтләрен күзәтергә, сүзләрен комсызланып тыңларга керештем.* А. Шамов.

2. Нәрсәне дә булса читтән карап-тикшереп, аның булу-булмавын, характерын, ни эшләвен һ. б. ачыклау, билгеләү. *Дошманны күзәтү өчен, камышлык эченнән ярык ачып, көймәгә перископ куйдык.* Ә. Айдар. *Взвод командиры траншеяда баскан һәм, кулын каш өстенә куеп, алгы кырыйны күзәтә иде.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Күзәтү өчен билгеләнгән, күзәтү алып барыла торган. [*Манара*] *бер үк вакытта чаң*

манарасы да, сакчылар өчен күзәтү башнясы да булып хезмәт иткән. СССР тарихы.

3. Берәр кешене фаш итү, тоту һ. б. ш. максатлардан чыгып, сагалап-тикшереп, карап йөрү. [*Хәйри:*] *Гомәр Гаязов әйткән большевикларны күзәтү өчен вокзалга, кымызчылар ята торган башкорт авылларына берничә кеше җибәрсеннәр.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Кемнең дә булса интересларын яклау, файдасын кайгырту; шул максаттан чыгып эш итү.— *Советлар --- ни булса да безнең ише кешеләрнең файдаларын күзәтәләр.* Һ. Такташ. *Нәгыйм монда әйтелгән бөтен сүзләргә катнашлык күрсәтүдән төбендә бер генә теләк күзәтә.* Ш. Камал.

5. *күч.* Берәр нәрсәне булдырырга тырышу, нәрсәгә дә булса ирешү өчен эш алып бару. *Киләчәктә шундый күңелсезлекләр булмауны күзәтергә кирәк.* Ф. Бурнаш.

6. *күч.* Өйрәнү, тикшерү. *Такташның үсешендәге --- борылышны күзәтү --- безгә бик кызык мисаллар бирә алыр.* Г. Нигъмәти.

7. *и. мәгъ.* Бер-бере белән бәйләнгән фактлар, вакыйгалар, күренешләр һ. б. турында кыскача белдермә, обзор. *Газетада минем хәрби шигырьләр турында --- кыска гына бер күзәтү язарга уйламыйсыңмы?* М. Җәлил.

КҮЗӘТҮЧЕ *и.* **1.** Үзенең профессиясе, хезмәте буенча кемне яки нәрсәне дә булса күзәтү эше белән шөгыльләнүче. *Бәлки дошман разведкасын бүтән күзәтүчеләр дә күреп алганнардыр.* Г. Әпсәләмов.

2. Разведка эшен башкаручы работник, разведка агенты. *Күзәтүчеләребез аның тегендә — Колчак ягында, шәп кәһарман булып, телләрдә йөргәнен хәбәр иттеләр.* Г. Ибраһимов.

3. Газета-журналда, радио-телевидениедә обзор ясаучы.

КҮЗӘТҮЧӘН *с.* Күренешләрнең, фактларның башкалар игътибарыннан читтә кала торган үзенчәлекләрен күрә, сизә ала торган. *Ул бик күзәтүчән һәм сизгер бала булса кирәк.* М. Җәлил.

КҮЗӘТҮЧӘНЛЕК *и.* Күзәтүчән булу, күзәтүчән кеше булу.

КҮЗӘҮ *ф. диал.* Карау. *Күзәми очкан кош кунарга агач тапмас.* Мәкаль.

КҮЗҮЛӘН *и. бот. к.* күз үләне (уты).

КҮК I *и.* **1.** Җирдән югарыга караганда гөмбәз сыман булып күренә торган һава пространствосы. *Таң нуры да күкнең көнчыгыш ягын алып бетеп килә.* Г. Ибраһимов. *Дә күктә самолетлар очалар.* Д. Аппакова.

2. Җирне чолгап алган дөнья (галәм) пространствосы. *Күктә йолдызлар балкый.* Р. Ишморат. *Җирнең күктәге башка яктырткычлар кебек үк күк җисеме булуы --- беленде.* Астрономия.

3. *күч.* Дини карашлар буенча: алла, фәрештәләр һ. б. ш. рухлар яши торган урын. *Күккә баскыч куеп, фәрештәләрнең серләрен урларга менә торган җенләрнең өйләре дә күз җитмәслек биек булгандыр кебек сизелә иде.* Г. Тукай. || *сөйл.* Алла һәм фәрештәләр.— *Без икебез дә язмышның үги балалары! Ерак күк безнең аһ-зарларга колак салмый.* Г. Ибраһимов.

4. *күч. шигъ.* Билгеле культура һәм социаль-тарихи үзенчәлекләр белән характерлана торган кешелек җәмгыяте. *Мең өч йөз еллар шәрык күген Каплап торган тәрәт чүпрәген яндырабыз бүген.* Һ. Такташ.

5. *с. мәгъ.* Астрономиядә кулланыла торган, астрономик. *Күк экваторы. Күк меридианы.* □ *Күк сферасы дип уйланма шар өслегенә әйтәләр.* Астрономия.

6. *рәв. мәгъ.* **күккә.** Югарыга, югарыга табан. *Составның нәкъ уртасында — --- авызын күккә күтәреп торган ике туп.* Ш. Усманов. *Аяз төннәрдә ач бүреләрнең күккә карап улаганнарын ишетәм.* Г. Ибраһимов.

Күк бите — *к.* күк йөзе. *Көнбатышына таба күк битеннән әкрен-әкрен пәрдә тартыла.* М. Җәлил. **Күк гөмбәзе** — *к.* күк йөзе. *Ай йөзә күк гөмбәзендә, Тын, бәхетле елмаеп.* Н. Исәнбәт. *Бервакыт күзен ачып җибәрсә, инде зәп-зәңгәр күк гөмбәзе исәпсез-хисапсыз йолдызлар белән бизәлгән булган.* Г. Гобәй. **Күк гөрелдәү (гөрселдәү)** — *к.* күк күкрәү. *Тагын күк гөрелдәде, тагын яшен чалтырады да, чиләктән койган шикелле итеп, яңгыр яварга тотынды.* Ф. Әмирхан. *Менә ераста — урман артында яшен яшьнәде, күк гөрселдәде.* Г. Гобәй. **Күк итәге (чите)** — күкнең горизонт линиясе өстендәге өлеше, офык. *Күк итәгенә ут кабып, дала өсте яктыра башлагач, [алар] бер чокырга яшеренделәр.* И. Гази. *Кояш баткач, күмердәй Утлана күк читләре.* Н. Исәнбәт. **Күк йөзе** — күк I (1 мәгъ). *Алар Габдулла абзыйның квартирасыннан чыкканда, күк йөзе ачылган, йолдызлар үтә якты бер нур белән ялтырап яналар иде.* Г. Ибраһимов. **Күк көймәсе (чатыры)** — күкнең күренә торган пространствосы. *Төсе уңа төшкән күк көймәсе тагын да биегәйде һәм ачыкланды.* Г. Бәширов. *Баш очларында гына йолдыз атылды: күк чатыры буйлап кадалып төште.* И. Гази. **Күк күкрәү** — 1) яшен яшьнәгән вакытта шатырдау, шартлау барлыкка килү. *Менә әллә нинди күк күкрәгән, Яшен аткан тавышлар ишетелде.* Ш. Мөхәммәдев; 2) *и. мәгъ.* яшен яшьнәгән вакытта барлыкка килгән шатырдау, дөбердәү яисә шартлау тавышы. *Күк күкрәве тагын да куәтләнде дә чалтырап суккан яшен тавышы бөтен дөньяны яңгыратты.* Ф. Әмирхан. *Ишетелә ямьсез болыттан Куркыныч күк күкрәве.* Н. Исәнбәт. **Күк җисеме** — йолдызара һәм планетаара пространствода булган җисем. *Кош --- җир йөзенә тереклек китерүче күк җисеменең чыгуын тәбриклә сайрап җибәрде.* Ш. Хөсәенов.

◇ **Күк белән ябылу (каплану)** — берәр нәрсәнең түбәсе ябылмаганны белдерә. **Күк кабагы (капусы) ачылу** — 1) дини карашлар буенча: ураза бәйрәменнән бер көн элек — „кадер киче“ндә күк йөзе бик нык яктырып китү (бу яктыру күктә болид атылуга бәйләнгән була; бу вакытта кеше нинди теләк тели, шул теләк кабул була, үтәлә, имеш). *Күк кабагы ачылуын көттем һаман да зар булып, Күк кабагы урынына каплады күкне зур болыт.* М. Гафури. *Имеш, күк кабагы ачылуын күргән кеше бәхетле була.* К. Латыйпов; 2) берәр нәрсәнең үтәлүе, башкарылуы өчен зур мөмкинлекләр тууны яки берәр кешенең бәхете артып торуны, уңышлары күп булуны белдерә. *Аның өчен бүген күк кабагы ачылган көн.* Х. Кәрим. **Күк капугы ачылу** *иск.*— *к.* күк кабагы (капусы) ачылу. *Күк капугы ачылганын күргән бер башкорт --- дога кылган: „Ярабби! Иртәгә бер телем ак күмәч белән май ашасам иде!“* Г. Тукай. **Күк (күкләр) күкрәтү** — 1) бик көчле тавыш күтәрү, көчле тавыш белән дер селкетү. *Минем дус та, күкләр күкрәтеп, Күрсәтәдер илнең ныклыгын.* М. Җәлил; 2) бик зур җанлылык уяту, шау-шу күтәрү, шаулау. *Күк күкрәтеп Гөрлә, Москва!* Ә. Ерикәй; 3) бик нык шау-шу күтәреп ачулану, тиргәү. *Ул башта әшчеләрне коры тотмакчы булды. --- Өсләрендә күкләр күкрәтә иде.* Ш. Камал. **Күк терәве** — бик озын кеше турында.— *Миңнулла, озын шайтан, күк терәве, аны ярлылар кәгазенә кертергә теләми.* И. Гази. **Күккә (күкләргә) ашу** — 1) күккә күтәрелү, һавага күтәрелү. [*Габдулла:*] *Ягез, авыл балаларының таза йөрәкләреннән чыккан шатлык җырлары күкләргә ашсын!* М. Фәйзи; 2) дини карашлар буенча: күккә (3 мәгъ.), алла, фәрештәләр яшәгән урынга күтәрелү (берәр

изге турында). *Бу вафасыз дөнья әчләрендә --- Тәхетләргә баскан, күккә ашкан Сөләйман нәби дә калмаган.* Г. Тукай. **Күккә күтәрелү** — җимерелү, җимерелеп юкка чыгу. *Күпер, шартлап, күккә күтәрелде.* И. Гази. **Күккә күтәрү, күккә күтәреп (чөеп) мактау** — чамадан тыш мактау. [*Заһиди*] *укытучылар арасында да, укучылар алдында да аны күкләргә чөеп мактый.* М. Әмир. [*Сәгадәт:*] *Хафиз белән аның иптәшләре Хафизаны мактап яңа көй чыгарганнар. Хафизаны бөтенләй күккә күтәргәннәр.* Г. Камал. **Күккә очыру (күтәрү)** — юк итү, җимерү, юкка чыгару. *Җир йөзен каплап, ташып килгән Наполеон яуларын Бер өрүдә көл итеп күккә очырган дөнья бу.* Ә. Исхак. **Күкнең төбе тишелү** — яңгыр нык ява башлау турында.— *Сибәли башлады, күкнең төбе тагын тишелде,— диләр алар.* А. Шамов. **Күктән иңү** — дини карашлар буенча: алладан килү, алла тарафыннан җибәрелү. *Күңлең — җиргә күктән иңүче рәхмәт юлы.* Г. Тукай. **Күктән көтү, күктән төшкәнне көтү** — хыялда гына өмет итү, берәр булмас нәрсәне өмет итү; бернәрсә дә эшләмичә, алладан өмет итү. [*Акбирдин:*] *Кандырга без суны күктән көтмибез, җирдән эзлибез.* К. Тинчурин. **Күктән сөрелү** — дини карашлар буенча: алла, фәрештәләр һ. б. ш. яшәгән урыннан куылу. *Ут белән күктән сөрелгән бер усал шайтан кеби, Сөрдисә мәҗлестән, ул дингә сыенган Мостафа.* Г. Тукай. **Күктән төшү** — 1) көтмәгәндә килеп чыгу, уйламаганда килеп чыгу, көтмәгәндә булу. [*Шәмси:*] *Шәрәф өчен күктән төшкән рәхмәт фәрештәсе булдың инде, рәхмәт төшкере.* М. Фәйзи; 2) тирә-якта барган күренешләрне, булган хәлләрне аңламау, төшенмәү турында. *Була иде аның шундый минутлары, барлык нәрсәгә күктән төшкән кеше кебек карый башлый иде.* И. Гази; 3) уйнаштан туу, зинадан туу; никахсыз туу. [*Бибкәй:*] *Берәүләрнең баласы бар икән. Ирсез көе күктән генә төшкән бала шулай газиз була инде ул.* М. Фәйзи.

КҮК II *с.* **1.** Спектрның иң төп төсләренең берсе: зәңгәр белән шәмәхә арасындагы төс; шул төстә булган. *Күк күгәрчен.* □ *Күл читләре күк урман, Күтәрелә күк томан.* Ш. Маннур. || Салкыннан яки бәрелүдән шундый төскә кергән (иреннәр, тән һ. б. турында). [*Шәкертнең*] *чәче җиту, яңак сөякләре чыккан, иреннәре күк, күзләре ачык көе хәрәкәтсез ята, үзе җиңел генә һаман сулый иде.* Ш. Камал.

2. Ат төсе турында: аксыл соры төстәге (кайбер диалектларда соры төстәге тимер күк атны да күк ат дип йөртәләр). *Ул арада Нәфисәнең күк атын җиккән мыек Шәмсетдин килеп туктады.* Г. Бәширов.

Күк агач — каеннар семьялыгыннан яфраклы каты агач яки куак. *Катнаш урманнарда --- корычагач (ясень), күк агач (граб) үсә.* Дөнья кис. геогр. **Күк билчән** *бот.*— оешма чәчәклеләр семьялыгыннан вак чәчәкләре себеркәчле укмаш чәчәк булып җыелган чүп үлән; *русчасы:* осот. **Күк бөрлегән** *диал.— к.* кара бөрлегән. **Күк кура җиләге** *диал.— к.* күк бөрлегән. **Күк сөт** *сөйл.*— өсте алынган сөт, сепараторда каймагы аерып алынган сөт. *Гайшәнең ничә елга бер килгән әнкәсен сыйларга каты арыш икмәге белән өсте алынган күк сөттән башка әйбере дә юк иде.* Г. Ибраһимов. **Күк сусын** *бот.*— эре матур чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* ирис. **Күк таракан** *диал.— к.* кыргаяк. **Күк чәй** — *к.* яшел чәй. *Кыз утырды безнең каршыбызга, Баллап, сөтләп күк чәй эчерде.* М. Җәлил. **Күк ютәл** — буылып-буылып ютәлләүдән гыйбарәт йогышлы авыру (балаларда була), бума ютәл; *русчасы:* коклюш. **Күк җиләк** — арчаннар семьялыгыннан күкчел кара төстәге җиләк бирә торган ярым куак һәм аның җиләге; *русчасы:* голубика. *Мүк үскән җирләрдә --- күк җиләк, мүк карлыганы күп була.* Физ. геогр.

КҮК III *бәйл. сөйл.* Кебек, шикелле. *Алда бар күк ниндидер карачкы.* Н. Исәнбәт. *Баскан җирдә таш күк каттым мин.* Б. Рәхмәт. *Беркөн кинәт ерактан Тавыш килгән күк булды.* Ә. Исхак.

КҮК-АЛА *с.* Нинди дә булса таплары булган аксыл соры төстәге (ат төсе турында). *Минем атым күк-ала, Акрын басып күп ала.* Җыр.

КҮКБАШ *и. бот.* **1.** Лаләчәләр семьялыгыннан чуар чәчәкле үсемлек; *русчасы:* рябчик. *Алар арасыннан Мысыр мәгән, күкбашны һәм талны бик җиңел танып була.* Робинзон әзл.

2. *диал. к.* күкчәчәк.

КҮКБҮЗ *с.* Аксыл соры төстәге (ат төсе турында). *Җаның булса, уян, сикереп күкбүз атка мен!* М. Гафури.

КҮКБҮЗАТ *и.* Тимерказык янындагы бер йолдыз. *Акбүзат йолдыз, Күкбүзат йолдыз, Тимерказык бер ялгыз.* Мәкаль.

КҮКЕ *и.* **1.** Йомыркаларын башка кошлар оясына сала, көзен көньякка китә торган урман кошы. *Кайсы агач башындадыр, Күке авазы бирә ерактан.* З. Мансур.— *Баш очымда күке кычкырып җибәрде, гадәт буенча мин санарга тотындым.* И. Гази.

2. *күч.* Бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүче кеше.

Күке сабыны *бот.*— канәферсыманнар семьялыгыннан җете кызыл чәчәкле күпьеллык үлән үсемлек; *русчасы:* барская спесь. **Күке төкереге** — алмагачның яшь ботакларына ефәк корты салган күкәйләрдән гыйбарәт, диаметры бер сантиметр чамасы булган божра. *Күке төкереген күп әбиләр балага күз тимәсен өчен дә тагалар.* Ак юл. *Арматура чыбыклары юка ак боз белән капланганнар иде. Күке төкереге кебек өзек-өзек урыннары да бар.* А. Гыйләҗев. **Күке яше** *бот.*— тропик үсемлек һәм шул үсемлекнең чәчәге; *русчасы:* орхидея. *Күке яшенең тамыры тешкә охшаган ике бүлбе сыман була.* Робинзон әзл. **Күке җитене** *бот.*— мүкнең бер төре; *русчасы:* кукушкин лён. *Юеш урманнарда һәм сазлы болыннарда еш кына яшел мүк — күке җитене очрый.* Ботаника.

◇ **Күке баш** *сөйл.*— аңгыра кеше, тинтәк.

КҮКЕБАШ *и. бот.* Кыярчалар семьялыгыннан яз үсә торган, күк һәм миләүшә төстә чәчәкләре булган үлән үсемлек; *русчасы:* медуница. *СССРның урта һәм төньяк зоналарындагы урманнарда түбәндәге баллы үсемлекләр үсәләр: кырлыган, дәгил, клевер, мәтрүшкә, күкебаш --- һәм башка күп кенә үләннәр.* Умартачылык.

КҮКЕЛДӘҮ *ф. сөйл.* „Кәк-күк“ дип кычкыру (күке кычкыруы турында). *Яз килү белән, көне-төне ул күкелдәүдән бушамый.* Ак юл. *Күке күкелдәмичә майның яме булмый.* Мәкаль.

КҮКЕЛЕ: күкеле сәгать — вакыт турында сигналны сугып түгел, ә күке кычкырган кебек тавыш белән бирә торган сәгать. *Террасада чиктән тыш зур күкеле сәгать тора.* Д. Аппакова.

КҮКЕРТ *и.* Сары яки соры төстәге тиз кабына торган химик элемент (промышленностьта, авыл хуҗалыгында, хәрби эштә һәм медицинада кулланыла). *Айзадулла шешәдән калган аракының өстенә күп кенә төйгән күкерт салып, тешләрен кыскан килеш бик нык селкегәннән соң, шешә авызыннан болкылдатып чайкый-чайкый атның бугазына агызып бетерә.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Күкерте булган; составына күкерт кергән. *Күкерт кислотасы. Күкерт ятмалары.*

◇ **Күкерт кебек кабыну** — бик тиз ачулану, бик тиз ярсып китү.

КҮКЕРТЛЕ *с.* Үзенең химик составында күкерт булган. *Күкертле ангидрид. Күкертле шырпы.* □ *Аяклары авырганга күрә, аңар шушы көннәрдә күкертле сулар белән дәваланырга барырга кирәк иде.* Ф. Әмирхан.

КҮКЕРТЛӘНҮ *ф.* Күкерткә әйләнү; күкерткә манылу.

КҮКЕРТЛӘҮ *ф.* Күкерт белән эшкәртү; күкерткә ману.

КҮКИШ *и. гади с. к.* кәҗә тоягы. *Шунда караңгы булса да, Күргәндәй булды дус-иш; Җир кирәкме — хәзер көрәш, Юкса алырсың — күкиш.* С. Баттал.

КҮККҮЗ *и. к.* күкчәчәк.[*Шәмсегаян:*] *Элек, безнең заманда, арыш арасында күккүзләр була торган иде.* А. Гыйләҗев.

КҮК-КҮ, КҮК-КҮК *аваз изяр. к.* кәк-күк.

КҮКЛЕ *с. сөйл.* Күк төсле, күк төстәге. *Һәм ул ут чиксез матур: күкле, кызыллы, аклы, ди.* Г. Тукай. *Күкле күлмәк кигәнсең лә, Тәрәзәгә килгәнсең.* Ф. Бурнаш.

КҮКЛЕК *и.* Күк булу, күк төстә булу; күк төс. *Диңгезнең күклеге. Күкнең күклеге.*

КҮКЛЕ-ЯШЕЛЛЕ *с.* 1. Күк һәм яшел булган; күк, яшел һәм алар арасындагы төстә булган. *Самовар янына йөгереп килгәндә, ул инде утырган җиреннән бер якка кыйшаеп төшкән, сары җиз ниндидер күкле-яшелле төскә кергән иде.* Ә. Фәйзи. [*Хәлим*] *тәрәзәнең күкле-яшелле пыяласы аша ишек алдына карап утырды.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Тамак төбе белән әйтелгән, карлыккан (тавыш турында). *Шәрифҗан, йодрыкларын кинәт баш өстенә күтәреп, күкле-яшелле тавыш белән кычкырып җибәрде.* И. Гази. || *сөйл.* Каралган, бик нык бозылган (чырай турында). *Күкле-яшелле чырай.*

КҮКЛӘҮ *ф.* Тегәргә уңайлы, тигез булсын өчен яки тегелә торган нәрсәне кидереп үлчәп карарга хәзерләгәндә, аның кисәкләрен әнәне әре-әре атлатып тегеп беркетү; типчү. *Киемне беренче тапкыр кидереп үлчәп карауга хәзерләгәндә кыса итәккә күкләнә.* Йорт эшләре. || Әнәне әре-әре атлатып тегеп, җөй буен билгеләү.

КҮКРӘК *и.* 1. Гәүдәнең муеннан алып корсакка кадәр булган алгы өлеше.— *Балаларымны кыйнадым да, соңыннан үзләрен кызганып, күкрәгемә кыса-кыса еладым.* Т. Гыйззәт. *Чабышып килделәр дә, ат күкрәге белән бәрдереп, камчылар белән суктырып, сукачыларны куа башладылар.* И. Гази. || Гәүдәнең үпкә, йөрәк урнашкан өлеше. *Йөрәге күкрәгеннән сикереп чыгарлык булып типте.* Ф. Әмирхан. *Улем микроблары хәзер күкрәгемдә, Алдап булмас ахры аларны.* Һ. Такташ. *Газлы төтен йотып күкрәкләргә, Төтенсез саф дөнья салабыз.* Ш. Маннур. || *күч.* Кичерешләрнең, хисләрнең һ. б. символы; күңел. [*Сәлимнең*] *күкрәгендә --- бик күп төн йокыларын качырган көнчелек уты яңа бер көч белән кабынды.* Г. Әпсәләмов. *Хисмәт бүген, җиңгән сугышчы күк, Күкрәгенә шатлык яшергән.* Ш. Маннур. *Түгәрәк күл буен мин буйладым, күкрәгемнән ташкач уйларым.* Ф. Бурнаш.

2. Хатын-кыз гәүдәсенең алгы яктагы өске өлешендә калкып торган сөт бизләре. *Сафа* [*Рәүфәнең*] *тырпаеп торган тыгыз күкрәкләрен, төз аяклары янып, ләззәтләнеп кararга тотынды.* А. Шамов.

3. Киемдә кеше гәүдәсенең шушы өлешенә туры килгән урын, киемнең алдагы өске өлеше. *Аның гимнастерка күкрәгендә Кызыл Байрак ордены һәм медальләр белән гвардеец билгесе күренеп калды.* Г. Бәширов. || *сы мәгъ.* Киемнең күкрәк өлешендә булган. *Каюм --- өченче көн һәм кичә язган конспектларын күкрәк кесәсеннән ашыкмыйча гына чыгарды.* Ш. Камал.

4. *шигъ.* Табигатьтә нинди дә булса бер урынның (мәсәлән, елга, җир һ. б.) өсте, өслеге. *Ләкин* [*дулкыннарның*] *көчләре җитми, сугылалар-сугылалар да Идел-ананың киң күкрәгенә кире кайтып яталар.* Г. Ибраһимов. *Таулар аша кырлар күкрәгенә Түшәләләр тигез шоссе.* Ә. Ерикәй.

Күкрәк авызы — күкрәк читлегендәге иң өске кабырганың күкрәк сөягенә тоташкан урыны. [*Суфиянең*] *муены нечкә генә, күкрәк авызына тоташкан урыны уймак сыярлык булып чокырланып тора.* А. Расих. **Күкрәк авыруы** *сөйл.*— үпкә авыруы, туберкулёз. *Шул елларда күкрәк авыруы белән җәфаланып йөргән Горький, әсәрләрен бастырып, әз булса да гонорар алуны, дәвалану өчен көньякка — Кырымга китүне хыял итә башлый.* Г. Нигъмәти. **Күкрәк бакасы** *сөйл.*— күкрәк кысу авыруы, йөрәк авырту чире; стенокардия. **Күкрәк баласы** — *к.* имчәк баласы. **Күкрәк зәхмәте** *сөйл.*— *к.* күкрәк авыруы.— *Менә шул әхмәтҗан нәкъ синең кебек күкрәк зәхмәте белән авырып ятты.* А. Шамов. **Күкрәк сөяге** *анат.*— күкрәк читлегендә алгы яктан кабыргалар тоташкан тар һәм яссы сөяк. *Өстәге 10 пар кабырга --- күкрәк сөяге белән тоташа.* Анатомия. **Күкрәк хасталыгы** *кит.*— *к.* күкрәк авыруы. [*Апам*] *күкрәк хасталыгы белән вафат булды.* М. Гафури. **Күкрәк читлеге (куышлыгы)** *анат.*— кешедәге сөяк системасының күкрәк умырткаларыннан, кабыргалардан, күкрәк сөягеннән гыйбарәт өлеше. *Төн урталарына таба аның йөрәге күкрәк читлегеннән бәреп чыгардай булып ярсырга тотына.* Г. Бәширов. *Күкрәк куышлыгы --- эчендә йөрәк һәм үпкәләр --- урнашкан.* Анатомия.

◊ **Күкрәк белән каршы тору** *юг.*— бөтен көч белән каршы тору, бөтен көчне биреп көрәшү. *Милләт өчен җан бирәчәк кәһарманнарга да аяк чалмак әстәдекләрендә каләмебез вә күкрәгебез илә каршы торабыз.* Г. Тукай. **Күкрәк белән саклау (яклау)** — кемне яки нәрсәне дә булса (мәсәлән, туган илне) яклап, саклап батырларча сугышу. [*Каюм:*] *Авылның һәммә ярлы һәм урта хәлле крестьяннары үзләренең Совет властен күкрәкләре белән саклаячакларына --- нык ышанабыз.* Ш. Камал. *Ташлап киттем тыныч иҗатымны --- Миңа бәхет биргән Туган илне Күкрәк белән саклап калырга.* Ә. Ерикәй. **Күкрәк кагу (сугу)** — берәр нәрсә белән мактану, шапырыну; сүзнең, сөйләүнең ышандыру, тәэсир итү көчен арттыру өчен яки масаеп, күкрәккә куллар белән бәрепбәреп алу.— *Анда синнән башка да чыгучылар булды. Күлмәк изүләрен ертып, күкрәк сугып та сөйләшеп карадылар.* Ш. Усманов. **Күкрәк киереп** — 1) үпкәләргә тулы сулыш алып, бөтен көч белән сулап. *Рәхәт соң, валлаһи, шундый чакларда киң тугайларда күкрәк киереп печән чабулар!..* Г. Ибраһимов; 2) бөтен көч-куәтне биреп, бөтен көч-куәт белән. *Кемгә кадерле яктылык, ирек, Саклар ул аны күкрәген киереп.* Г. Камал; 3) горур, үз көченә үзе ышанып. **Күкрәк киерү** — масаю, артык һавалану; мактану. [*Байбикә:*] *Баеган саен күкрәген киерә бит ул.* Д. Аппакова. [*Закир:*] *Әллә кем булган булып күкрәкләрен киереп сөйләп яткан була бит.* Г. Камал. **Күкрәк сызылу** — кайгыру, көенү. *Уйлыйм, оча күңелем, ялкынлана, Кызулана йөрәк ташкыны, Күкрәккәем сызыла.* М. Җәлил. **Күкрәк сөте** *шигъ.*— баланы тукландыру өчен хатын-кызларның күкрәк бизләре бүлеп чыгарган сөт. [*Ана*] *Әллә ничә* [*уяның*] *Биргән сиңа күкрәк сөтен.* М. Гафури. **Күкрәк тавышы** — яңгыравыклы калын тавыш; бик төптән килгән яңгыравыклы тавыш. *Шибай кантун күкрәк тавышы*

белән бөтен мәҗлес өстеннән гөрләп әйтте. Г. Ибраһимов. **Күкрәк тутырып** — үпкәләргә һава тулганчы. *Аның күкрәк тутырып һаваны иснәсе, кычкырып җырлап җибәрәсе килде.* Ш. Усманов. **Күкрәктән чыккан тавыш** — *к.* күкрәк тавышы. *Аның күкрәктән чыккан тавышы ишетелде.* Ш. Усманов.

КҮКРӘКЧЕН *и. иск.* Борынгы заманда күкрәкне саклау өчен киелә торган кечкенә калкан яки көбә рәвешендәге сугыш киеме.

КҮКРӘКЧӘ *и.* 1. *этн. иск.* Татар хатын-кызларының күлмәк эченнән күкрәкне каплап кия торган эчке киеме. [*Миңлебикә:*] *Бөтенесен исәпкә тыга. Хатыны садака итеп биргән күкрәкчәләргә кадәр.* Ә. Фәйзи.

2. Алъяпкычның күкрәкне каплый торган өлеше. *Тик бүрәнә өстенә баскан Гыйсми генә, ике кулын алъяпкыч күкрәкчәсенә тыккан килеш, --- тын гына карап тора иде.* А. Шамов. *Ак киез эшләпәле, бишмәт яки җиңсез камзул өстеннән күкрәкчәле киндер алъяпкыч япкан агайны очратсаң, шул безнең якның ялчысы инде.* И. Рәмиев.

3. *махс.* Борынгы вакытта һәм урта гасырларда: күкрәкне саклау өчен панцирь. *Күкрәкне бронза пластинкалардан эшләнгән күкрәкчә саклаган.* Бор. зам. тарихы.

КҮКРӘНҮ *ф.* Шау-гөр килү, шаулау, гөрләү. *Салмак кына тирән эрелек белән Ак самолет килә күкрәнеп.* Ш. Маннур.

КҮКРӘТҮ *ф.* Шау-шулату; шаулату; гөрләтү. *Күкрәтеп бар җир-күгеңне, Җен шикелле бер ир килә.* Н. Исәнбәт. *Киер яшь күкрәгеңне, әйдә күкрәт!* М. Җәлил.

КҮКРӘҮ *ф.* 1. *з.-сыз.* Күк күкрәп, яшен яшьнәгәндә көчле дөбердәү тавышы барлыкка килү. *Тагын яшен яшьни, Тагын күкри, Тагын шулай җилләр исәләр.* Һ. Такташ.

2. Яңгырау, яңгырау барлыкка китерү. *Күптән түгел генә күкрәп торган һәм дәһшәтле сугыш кыры булган Үзәнлекне тынлык каплады.* Ә. Исхак. *Габдулланың күз алдына --- җиз быргыдан күкрәп чыккан тавыш белән тамак кыра торган зур галим килеп басты.* Ә. Фәйзи.

3. *күч.* Гөрләп үсү, шаулап үсү, бик шәп булып үсү.— *Чәчәкләр күкрәрләр, --- карлар эрер.* Һ. Такташ.— *Эссе чүлләр күкрәп торган яшел кырларга, гөл бакчаларына әйләнер.* Р. Ишморат.

4. *күч.* Билгеле (данлыклы) булып яшәү; бик шәп яшәү. *Яшь вакытта яшьнәдем, көчле вакытта күкрәдем.* Г. Тукай. *Күкрәп яшә, Татарстан, Республикам минем.* Җыр.

5. *рәв. мәгъ.* **күкрәп.** Бик яхшы, шәп, мул булып. *Куәтле зур экскаватор килә дә, шул күкрәп үсеп утырган ашлыкны икегә ярып, тирән канау казып китә.* А. Әхмәт. *Безнең кырда зәңгәр гөлләр күкрәп үсәрләр.* Һ. Такташ.

◇ **Күкрәп торган** — көче ташып торган, көчле, таза (кеше турында). *Мин бит әле күкрәп торган егет, Сокланырлык гомерем үтмәгән.* Ш. Маннур.

КҮКРӘҮЛЕ: күкрәүле яңгыр — яшенле яңгыр. *Җир йөзен сафландыргыч давыллы, күкрәүле яңгыр киләсен алдан ук сизенеп, чәрек агач куышын эзләгән ябалак.* К. Нәҗми.

КҮКСАГЫЗ *и.* Каучук бирә торган күпьеллык үсемлек.— *Күксагыз безнең армиягә бик кирәк, аннан резина ясыйлар,— дип әйтергә кушты* [*Хәйдәр*]. Г. Бәширов.

КҮКСЕЛ *с. Ким. дәр. к.* күк. Аксыл күк, сыек күк; күк төскә тартым булган, күгелҗем. *Канатланып оча зур эшелон, Күксел төтен кала таралып.* Ф. Кәрим. *Сания --- өстенә ак бизәкле күксел крепдешиннан тегелгән җиңсез күлмәк кигән яшь, ачык чырайлы хатынны күрде.* М. Әмир.

КҮКСЕЛЛЕК *и.* Сыек күк төс, күксел төс. [*Яшьлек*], *Зәңгәр диңгез төсле, Күкселлеккә төренеп ялтырар.* М. Җәлил.

КҮКСЕЛЛӘНҮ *ф.* Күксел төскә әйләнү, күксел төскә керү. *Аның яралары --- күкселләнеп җөйләнгәннәр иде.* А. Шамов. [*Шакирның*] *чигә тамырлары күкселләнеп бүрттеләр.* Г. Минский. || Күксел булып күренү, күксел төстә булып күренү. *Газинур күкселләнеп торган үзәннәрдән, урман буйларыннан зур күзләрен алмады.* Г. Әпсәләмов. *Бәке Чаган бозы өстендәге күкселләнеп яткан кар уртасында караеп, чумгылланып тора.* Ә. Фәйзи.

КҮКСЕЛ-ЯШЕЛ *с.* Күкселләнеп торган яшел. *Хәтфә уҗымнар өстеннән бездәгечә күксел яшел дулкыннар йөгерешә.* Р. Төхфәтуллин.

КҮКСУ *с. к.* күксел.

КҮКСӘҮ *ф. диал.* 1. Ютәлләү (авыру вакытында).

2. *и.* Ютәл авырулы кеше.

КҮКСҮ *ф.* Күгәрү, күгәрүдән начар, ачы тәм керү (ашлык, он һ. б. ш. турында). *Тыгын өй эче күксегән ис белән тулган иде.* А. Расих. *Малик --- шулар бәрабәренә күксегән арыш оны өләшеп ятмас иде.* И. Гази.

КҮКТАШ *и. сөйл.* Бакырны күкерт кислотасында эретеп алынган күк төстәге тоз; бакыр купоросы.

КҮКФАРЫЗ *и. иск. к.* күкташ. *Уземне көзгедән карыйдыр идем дә колакларымның күкфарыз күк икәнен белә идем.* Г. Газиз.

КҮКЧЕЛ *с. диал.* Беркадәр басынкы, карлыккан тавышны хәтерләткән (тавыш турында). *Олуг чаң тавышы озаеп торган хәлдә туктап тора. Ул тавыш үзе күкчел.* Ш. Камал.

КҮКЧӘЧКӘ *и. сөйл. к.* күкчәчәк. *Күкрәп утырган күкчәчкә арасындагы кечкенә өстәл тирәсенә утырыштык.* М. Әмир.

КҮКЧӘЧӘК *и.* Күбрәк уҗым ашлыклары чәчүлекләрендә очрый торган ачык күк чәчәкле чүп үлән; *русчасы:* василёк.

КҮКШЕЛ *с. диал. к.* күксел. *Бер әби күкшел тамырлары беленеп торган ябык куллары белән үзенең кечкенә төбенен чишә алмый азаплана иде.* Г. Сабитов. *Башына төсе уңган пилотка, өстенә күкшел майка кигән --- Илгизәр --- яр буенда торган җиңгәсенә күтәрелеп карады.* Г. Бәширов.

КҮКШЕЛЛӘНҮ *ф. диал. к.* күкселләнү.

КҮКШИН *и. диал. к.* кувшин. [*Дәүләтьяров белән Якуп*] *иртән, пристаньга чыгып, биш йөз сумга бер күкшин кызарганчы кайнаган сөт алып керделәр.* И. Гази.

КҮКШӘ *и. зоол.* Чыпчыклар отрядыннан кыш көне җылы якка китә торган, урманда яшәүче кош. *Күкшәләр бик куркаклар; аларның ачык чуар каурыйлары ачык урыннарда тилгәннәрнең һәм башка ертык кошларның күзенә ташлана.* Робинзон эзл.

КҮКШӘКОШ *и. сөйл. к.* күкшә. *Күкшәкош, кызылтүш, миләш чыпчыгы бик еш килде хәзер урманнан.* Г. Гобәй.

КҮКӘЙ *и.* 1. *биол.* Ана җенес күзәнәге. *Күкәй һәм сперматозоид — бер төрле булмаган шартларда үскән ике организмның тереклек эшчәнлеге продуктлары.* Анатомия.

2. *биол.* Ана бөҗәкләр сала торган шундый ук күзәнәк. *Ана коңгызлар туфракны казып керәләр дә шунда киндер орлыгы зурлыгындагы ярым үтә күренмәле күкәйләр салалар.* Зоология.

3. *биол.* Ата җенес күзәнәкләре ясала торган җенес бизе һәм кешедә, хайваннарда була торган эчке секреция органы.

4. *сөйл. к.* йомырка. *Саниянең чебиләре әллә кайчан тавык булып җиткән, күкәй салалар.* Г. Гобәй. *Хәкимҗан --- кесәсеннән тавык күкәйләре алып, аларны зур саклык белән өстәлгә куя башлады.* А. Әхмәт.

Күкәй күзәнәк *биол.*— *к.* күкәй (1 мәгъ.). *Күкәй күзәнәк протоплазмадан һәм төштән тора.* Анатомия. **Күкәй тәбәсе** — *к.* йомырка тәбәсе. *Чәй дә кайнады, күкәй тәбәсе дә куырылды.* Н. Фәттах.

◇ **Күкәй күз** *гади с.*— акаеп торган күз, акай күз, зур күз. [*Ибрай:*] *Чумара Садрыйның күкәй күз Галимәсе кебекләргә калса, артыңа әйләнеп карамый өч көн тоташ йөгер.* М. Фәйзи. **Күкәй эчендәге сары кебек** — 1) бик саклап, кадерләп тора торган берәр кеше яки берәр әйбер турында; 2) тормыш авырлыклары күрмәгән яшь кеше турында.

КҮКӘЙАШАР *и. зоол.* Башка бөҗәкләрнең күкәйләре эченә күкәй сала торган паразит бөҗәк.

КҮКӘЙЛЕК *и. биол.* Күкәй күзәнәк ясала торган женес бизе.

КҮ-КҮ *аваз ияр. к.* кәк-күк. *Ә мәгънәсез кәккүк, мактанып, Тик лыкылдый, үзенә таң калып: Бар белгәне „кү-кү" аныкы.* М. Җәлил.

КҮЛ I *и.* 1. Бөтен яктан да ярлар белән уратып алынган табигый сулык. *Ике аккош килеп төште Күл буена камышка.* Җыр. *Урманнар, сазлар, таулар һәм исәп-хисапсыз күлләр, елгалар белән Карелия җире сугыш операцияләре алып бару өчен иң кыен урыннарның берсе санала.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Күлдә яши торган. *Күл балыгы.* □ *Төнге тынлыкта бары өзлексез черелдәгән чикерткә тавышлары арасында күл бакаларының бакылдашулары --- ишетелгәләп тора.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Күлдә йөзү өчен билгеләнгән. *Күл флоты.*

2. Су түгелеп, җыелып барлыкка килгән кечкенә сулык; күлдәвек. *Бу ташкыннан торып Калды бераз су. Күрер күзгә бу су — Бер кечкенә күл.* М. Гафури.

КҮЛ II *и.* Зур капчык (гадәттә чыптадан тегелгән була). *Җилкәдәге унар потлы күлләр, Үч иткән күк, җиргә тарталар.* Ш. Маннур.

КҮЛБУГА *и. зоол.* Челәннәр семьялыгыннан үкергән тавыш чыгара торган саз яки елга кошы. *Күлбуга үкергәндә борынын суга тыга, имеш. Чумдырып өргәнгә үкергән тавыш килеп чыга, имеш.* Ялкын.

КҮЛДӘВЕК *и.* Кар эрегәннән яки яңгыр яуганнан соң җыелып калган су. *Сәлимгәрәев, тәрәзә буена килеп, аның күлдәвекләр аркылы күлмәк итәкләрен җыеп сикереп чыгуын күзәтте.* Г. Ахунов. *Машиналар батып утырган чокыр-чакырлар, һәр җирдә җыелган су күлдәвекләре ялтырап яталар.* М. Хәсәнов.

КҮЛЕК *и. диал.* Камыштан һ. б. ш. үреп ясалган сумка.

КҮЛЕМ *и.* 1. Көндезге ял (кыр эшләрендә). [*Сәйдә җиңги:*] *Бер заман күлем җитә. Тамак ялгап алырга туктыйбыз.* С. Рафиков. *Алар өйләгә чаклы бер, өйләдән соң бер-ике генә тапкыр күлем ясыйлар, аны-сында да Локман ун-унбиш минуттан артык утырырга ирек бирми.* Х. Сарьян.

2. Кыр эшләре эшләгәндә билгеле бер вакыт эчендә башкару өчен бүлеп алынган җир мәйданы; кишәрлек. [*Мостафа:*] *Безгә бүген шушы күлемне* [*урып*] *бетерергә кирәк.* Ш. Камал.

КҮЛЛӘВЕК *и. к.* күлдәвек. *Борылманы үтүгә зур-зур күлләвекләр очрый башлады.* А. Гыйләҗев. *Ул ераклашкач, күлләвек аша сикерде, юлын дәвам итте.* А. Расих.

КҮЛМӘК *и.* 1. Махсус өлгедә тегелеп, эчке һәм тышкы кием буларак киелә торган кием, нигездә ике төрле була: 1) кофтадан гыйбарәт өске өлеше белән юбкадан гыйбарәт аскы өлеше бергә тоташтырылып бер бөтен тәшкил иткән кием (бу төрен хатын-кызлар кия). *Абыстай, асрау кызын ияртеп, ефәк күлмәкләрен чаж-чож иттереп, тутырган тавык шикелле, каретага менеп утырды.* Ш. Мөхәммәдев. *Башына яулык бәйләгән, озын алсу күлмәк кигән җиту кыз белән кара бишмәтле тәбәнәк килен икәү тораллар.* Г. Ибраһимов; 2) гәүдәнең өске өлеше өчен билгеләнгән кием (бу төрен ир-ат кия). *Гәрәй күлмәк өстеннән билен каеш белән буган.* М. Фәйзи. *Фазылның күлмәге кызыл икән, итәк читен кисеп алып, шлемга яңа йолдыз тектеләр.* Г. Гобәй.

2. *диал.* Ана карынындагы туманың тышчасы.

Күлмәк итәге — *к.* итәк (1 мәгъ.). *Күлмәк итәкләрен кыстырган ябык гәүдәле, әрлән кебек җитез, яшь кенә хатын иде ул.* Ә. Фәйзи. *Маһи әби, каравылчыны каргый-каргый, күлмәк итәгенә җилләген салып, чүпләрен аерды.* М. Гали.

◇ **Күлмәктә туган** — эше уңа торган, бәхетле кеше турында әйтелә.

КҮЛМӘК-КҮНЧЕК *җый. и сөйл.* Күлмәк, эчке күлмәк һ. б. ш. киемнәр. *Гафифә, Хәмзә байның кызы, --- күлмәк-күнчек, кершән-иннек интереслары белән --- бик көлке халәттә күрсәтелә.* Ф. Әмирхан. *Аннары бит әле аның, әнисе әйтмешли, бүтән чыгымы да җитәрлек: күлмәк-күнчеге дисеңме, ашъяулыгы-сөлгесе...* Г. Бәширов.

КҮЛМӘКЛЕК *и.* 1. Күлмәк тегәргә яраклы тукыма; күлмәк тегү өчен билгеләнгән тукыма, материал. [*Садыйк:*] *Абыстагызның бүләге: Миңсылу белән икәвегезгә сатин күлмәклекләр.* Ш. Камал. *Ул миңа да, әнемә дә яңа түбәтәй һәм күлмәклек алып кайткан иде.* М. Гафури.

2. *с. мәгъ.* Күлмәк тегү өчен билгеләнгән, күлмәк тегәргә яраклы; күлмәккә җитәрлек.— *Дмма минем хатыныма да күлмәклек киндер кирәк.* Г. Тукай. — *Мәрвибану апа Хәйретдинова бер күлмәклек штапель белән бүләкләнә.* Ф. Хөсни.

КҮЛМӘКЧӘН *рәв.* Өске кием киеп тормыйча, күлмәк кигән килеш. *Берничә хатын күлмәкчән генә өй алдына йөгерешеп чыкты.* И. Гази.

КҮЛМӘК-ЫШТАН *җый. и.* Киемнең бер төре буларак күлмәк белән ыштан. *Күлмәк-ыштаннар илә вак балыклар сөзеп ята идек.* Г. Тукай.

КҮЛМӘК-ЫШТАНЛЫК *и.* Күлмәк һәм ыштан тегү өчен тукыма, материал. *Габденнасыйрга казакилык, балаларга күлмәк-ыштанлыклар, кәләпүшләр, пәкеләр чыгарып, сәкенең буш урынына таратты.* М. Гали.

КҮЛЧӘ *и. диал.* Божра, алка. *Насосның поршененда-гы күн тәгәрмәчләрне бастырып тора торган яссы күлчә бер кырыеннан бөтенләй яньчелгән.* Ш. Камал.

КҮЛӘГӘ *и.* 1. Бер яктан яктыртылган предметның икенче ягында барлыкка килгән караңгы чагылышы. *Сукыр лампа яктысында, күләгәсе белән бөтен стена-ны каплап, Миңнулла бик кызып сөйләде.* И. Гази. || Кояш, ай яктыртудан җир өстендәге предметларның икенче ягында барлыкка килгән караңгы чагылыш (бу чагылыш кояш, ай югары булганда — кыска, түбән булганда озын була). *Алар, малларны төшлеккә туплыйлар да, чиратлашып йокларга булалар: башта Газинур йоклый, аннары, күләгә өч чабатага кыскаргач, Мисбах йокларга ярата.* Г. Әпсәләмов. *Айның күтәрелүе белән кыскара торган агач күләгәләре Хәятның күңелендә хыялый картина тудырдылар.* Ф. Әмирхан.

2. Нәрсә белән дә булса капланып, кояш нурларыннан сакланган пространство, урын. *Тирләгән ябык атны, тугарып, күләгәгә бәйләделәр дә арбаны бушатырга тотындылар.* Г. Ибраһимов.— *Бик әйбәтләп Кара диңгез буйларында, кипарис агачлары күләгәсендә --- ял иттерим әле үзеңне.* Ш. Камал.

3. Карангыда **ачык** күренмәгән кеше, хайван яки берәр предмет; **аларның ачык** булмаган шәүләсе. *Урамда Караборын ачы-ачы өрә башлады, һәм тәрәзә алдында ике күләгә күренде.* Һ. Такташ. *Аның күз алдында бик зур кара күләгәләр чайкалып китә.* Ә. Фәйзи.

4. *махс.* Картинада, рәсемдә кешенең яки предметның иң аз яктыртылган ягын күрсәткән урын.

5. *күч.* Кешедәге эчке рухи хәлнең (гадәттә кайгылы, сагышлы хәлнең) йөздә, күздә чагылуы. *Шулай да Нәфисә аның көләч күзләренең әллә кай төшендә генә бераз пошыну күләгәсе дә күреп калды.* Г. Бәширов.

6. *күч.* Кайгылы, күңелсез күренешләрнең чагылышы; кайгы, күңелсезлек билгесе, галәмәте. *Залдан үлем күләгәсе үткән кебек тоелды.* Г. Ибраһимов.

7. *күч.* Нәрсәнең дә булса кире, начар ягы; начарлык. *Тормыш инде аның белән Габдулла арасындагы күләгәләрне җуеп ташлаган иде.* Ә. Фәйзи.

◇ **Күләгә (булып) төшү** — кемгә яки нәрсәгә дә булса, яисә аның яхшы исеменә тап төшү; яманаты чыгу. [*Илгизәр:*] *Бөтен комсомол оешмасы өстенә кара күләгә булып төшә бу.* Г. Бәширов. **Күләгә кебек (йөрү, бару, атлау һ. б.)** — тавышсыз-тынсыз, бернинди тавыш чыгармыйча. *Монахлар икенде белән ахшам арасындагы күләгә кебек тавышсыз-тынсыз гына йөриләр.* К. Нәҗми. *Якубны өйдә очрата алмагач,* [*Миңнулла*], *урамга чыгып, күләгә кебек шыпырт кына атлап, түбән очка таба төшә башлады.* И. Гази. **Күләгә кебек иярү** — арттан калмыйча йөрү, һәрвакыт янында йөрү. *Күләгә кебек ияреп, Янымда йөрде үлем.* Ә. Ерикәй. **Күләгәсе күмелеп тормау** — кая да булса китеп озак тормау, тиз кайту. *Гайрәтулла ул кая барса, шунда алтын тавына юлыга, китеп күләгәсе күмелеп тормады, әнә ничек баеп кайтты.* Ф. Хөсни. **Күләгә төшерү (ташлау)** — кемнең дә булса яхшы исеменә **тап** төшерү; аны хурлыкка, оятка калдыру. *Күләгә төшерергә теләгән даирәләр дә телләрен тешләргә мәҗбүр булдылар.* Ф. Әмирхан. *Шундый олы кешеләргә күләгә ташлау Хәдичә тәти каршында --- телгә алырга җирәнерлек яман бер әшәкелек иде.* Г. Бәширов. **Күләгә төшү** — шик төшү, тап төшү. **Күләгәдә калдыру** — 1) игътибарга алмау, исәпкә алмау; арткы планда калдыру. *Кадетлар министрлыгы --- Думаның яраксызлыгын күләгәдә калдыра.* В. И. Ленин; 2) кемнән яки нәрсәдән дә булса өстен чыгу; җиңү. [*Хәмдия:*] *Берәүгә хасланган мәхәббәтемне дә күләгәдә калдырырлык, күңелемне кол иткән көем бар.* М. Фәйзи. *Минем гөлчәчәк кырым Гарлемның* [*чәчәкләр үстерә торган шәһәрнең*] *гасырлар буенча килгән --- шөһрәтен күләгәдә калдырыр.* Ф. Әмирхан. **Күләгәдә калу** — игътибардан читтә калу, арткы планда калу. **Күләгәдәй тын** — тавыш-тынсыз, бернинди тавышсыз. *Нәфисәнең иптәшләре, кыяр-кыймас бригадирларына карашты-рып, күләгәдәй тын торалар.* Г. Бәширов. **Күләгә эчендә калдыру** — арткы планда калдыру, игътибардан читтә калдыру. *Жандарм ротмистрның, җиде төн уртасында атлы гаскәре белән, полициясе белән килеп, мәдрәсәне камап алуы, ишекләргә каравыл солдат куеп, озын төн буенча тентү ясавы ул шәкерт революциясе турындагы гайбәтләрне күләгә эчендә калдырды.* Г. Ибраһимов.

КҮЛӘГӘЛЕ *с.* Күләгә төшкән, күләгәләнеп торган; кояш нурларыннан ышыкланган. [*Сафа*] *Гөбенә елгасы буендагы куаклыкта бераз ял итәргә дип туктады. Күләгәле урын сайлап, ятып торды.* А. Шамов.

◇ **Күләгәлә як** — нәрсәнең дә булса начар, кире, тискәре ягы. *Бу колхозның --- аеруча кырчылык тармагы буенча эчпошыргыч күләгәле яклары бар иде.* М. Шабай.

КҮЛӘГӘЛЕК *и. к.* күләгә (2 мәгъ.). *Җәйнең иң кызу чакларында да аның төбендә салкынча күләгәлек була.* Г. Ибраһимов.

КҮЛӘГӘЛӘҮ *ф.* **1.** Күләгә барлыкка китерү, күләгә ясау; күләгә белән ышыклау, күләгә белән каплау. *Өстеннән зур-зур агачларның киң-киң ботаклары чыгып безнең юлыбызны күләгәләп тора торган озын бер койманы үткәндә, без тын гына, сөйләшми генә бардык.* Ф. Әмирхан. *Учарланып үскән карама агачы, безне кояшка пешермичә, өстебездә күләгәләп тора.* Ф. Хөсни.

2. *күч. сөйл.* Начар итү, начар итеп күрсәтү; таплау.

КҮЛӘМ *и.* **1.** Нәрсәнең дә булса озынлык, биеклек һәм киңлек ягыннан куб берәмлекләр белән үлчәнә торган зурлыгы. *Кубның күләме.* □ *Турыпочмаклы призманың күләме нигез мәйданы белән биеклеге тапкырчыгышына тигез.* Геометрия.

2. Нәрсәнең дә булса тышкы сызыклары буенча зурлыгы. *Анда уставта күрсәтелгән күләмнән бер карыш та артык җир юк иде.* А. Шамов. || Нәрсәнең дә булса микъдар ягыннан әүтәлеге. *Ул планны --- Аркадий Адольфович тәкъдим иткән күләмнән дә кыскартырга яисә бөтенләй архивка тапшырырга туры килер.* Ш. Камал.

3. Нинди дә булса күренеш, эшчәнлек һ. б. ш. ның җәелү дәрәҗәсе, колачы. *Октябрьдан соң --- киң күләмдә халык әдәбиятына да --- иркенләп үсәргә юл ачылды.* М. Җәлил. *Фронт штабы киң күләмдә һөҗүм башлау планын төзеде.* Ш. Усманов. || Нәрсәнең дә булса масштабы, сферасы. [*Егетләр*] *дөнья күләмендәге мәсьәләләр белән кызыксына башладылар.* И. Гази. *Авылга кайтып китү алдыннан, комсомол активын җыеп, шәһәр күләмендә җыелыш уздырылган иде.* М. Әмир.

КҮЛӘМЛЕ *с.* Күләме зур булган. *Күләмле әсәрләр.*

КҮЛӘ'МЧӘ: күләмчә авырлык — табигый хәлендә билгеле күләмдә алынган материалның авырлыгы. *Күләмчә авырлык — ул бер куб метр җисемнең килограммнар белән алынган авырлыгы.* Физика.

КҮЛӘНКӘ *и. диал.* Кояштан, кояш нурларыннан нәрсә белән дә булса ышыкланган урын, күләгәләнгән пространство. [*Вәли*] *тазартылган орлыкны, аннан күләнкәдә торган аксыл тимер тракторны күрсәтте.* Г. Ибраһимов. *Байтак себергәч, хәл алыр өчен, --- койма буендагы эскәмиягә барып күләнкәгә утырды.* Ш. Мөхәммәдев.

КҮЛӘТКӘ *и. диал. к.* күләгә (1—3 мәгъ.). *Стенага таба карап, аякларын җыеп, корышып яткан ул. Гәүдәгә таза түгелдер ахры, күләткәсе малайларныкы шикелле генә тоела.* Ш. Маннур.

КҮЛӘСӘ *и. диал.* Тәгәрмәч. *Дөнья — күләсә, әйләнә дә бер баса.* Мәкаль.

КҮМЕЛҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* күмү (1—7 мәгъ.). *Иске чүплектә чокырга күмелгән җирдән әллә никадәр бодай чыкты.* Г. Бәширов.

2. Нинди дә булса сыеклыкка яисә көпшәк матдәгә бөтен күләме белән тулысынча керү, бату, чуму. [*Әхмәт*] *барып төште тирән суга — күмелде.* М. Гафури. [*Елга*] *буендагы баткак юлда көпчәкләр күмелә башлагач, кучерлар, арбаларын ташлап, атка атланып качып киттеләр.* Ш. Усманов.

3. Берәр кешенең яки предметның өсте нәрсә белән дә булса каплану, өстенә бөрәр нәрсә куну. *Әнә хезмәтче: киң җилкәле, зур сакаллы, бөтен җире онга күмелгән бер бабай.* Г. Ибраһимов. *Өс-башлары карга күмелеп, бозланып каткан Кашшаф белән Фәрдәнә керәләр.* Р. Ишморат. || Кар, балчык, ком һ. б. ш.

астында калу; шундый нәрсәләр басып китү. *Көчле буран чыгып, чана юлы күмелә язганлыктан, ат бик әкрен барды.* Г. Гобәй. *Аңына килгәндә, Җамали үзенең яртылаш балчык астында күмелеп ятканын күрде.* М. Гали.

4. Каплап алыну, чолгап алыну (күп предметлар белән). *Шул ук көннәрдә шәһәрләрдәге коймалар боерык кәгазьләренә күмелделәр.* К. Нәҗми. *Күк йолдызлар белән күмелгән.* Һ. Такташ. || Җир өсте тоташтан үсеп утырган агачлар, үсемлекләр белән каплану. *Тезелеп киткән ак өйләр ямь-яшел булып утырган җимеш бакчаларына күмелгәннәр.* А. Әхмәт. || Агач, куак һ. б. үсемлекләрнең яфрак, чәчәкләр белән капланып алынуы турында. *Бирге яктан аксыл чәчәккә күмелгән алмагач бакчалары күренә.* М. Җәлил. || Йөзнең сакал-мыек белән капланулы турында. *Аның болай сөйләве, тирә-яны йонга күмелгән киң һәм көләч йөзенең рәхәтләнеп китүе Шәрәфи картка ошады.* Ш. Камал.

5. Нәрсә дә булса ябыну, нәрсә белән дә булса өсне каплау; берәр нәрсә арасына посу. *Митингтан соң Газинур авыл читендә, корыган бәрәңге сабакларына күмелеп, төнге секретта ята иде.* Г. Әпсәләмов. *Мулла --- зур толыбының якалары эченә күмелде.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Үз яныңа нинди дә булса бер эш белән шөгыльләнү өчен кирәкле әйберләрне бик күпләп кую, бик күпләп куеп утыру. *Искәндәр аны яткыра да үзе төн буе чертежларга күмелеп эшләп утыра.* Г. Гобәй. *Ул, газеталарына күмелеп, Якубны бөтенләй онытты: утыра да утыра.* И. Гази.

6. Нәрсәнең дә булса караңгылыкка чумуы яки яктылык белән чолгап алынуы турында. *Фонарь яктысы караңгылыкка күмелгән пычрак суларны төпсез күлләргә охшатып күрсәтә.* К. Нәҗми. || Төтен, томан һ. б. ш. эченә калу. *Бая гына үзенең коры һәм җылы һавасы, он исе белән ямь биреп торган өй эче яшел тәмәке төтененә күмелде.* Г. Минский.

7. *күч.* Тавыш, шау-шу белән тулу турында. *Берничә минут үтәр-үтмәс Боз диңгезе мотор җырына күмелде.* А. Алиш. *Землянка шау-шуга күмелде.* А. Әхмәт.

8. Ераклашып, берәр нәрсә эченә, арасына кереп күренмәс булу, күздән югалу. *Кулны болгый-болгый китте, Урамнарга кереп күмелде.* Ш. Маннур.

9. *күч.* Зур байлыкка, күп акчага, зиннәтле әйберләргә ия булу турында. *Әнә шулай итеп байлыкка күмелгән, алтынга чумган Парижның --- кыз-хатыннарны шундый юллар белән икмәк табарга мәҗбүр итүе ачык факт булып кала.* Г. Гали. || Зиннәтле, затлы киенү турында. *Күз карашларында шул алтыннар, ефәкләр эченә күмелгән шат йөрүчеләр арасына барырга теләсәләр дә, үзләрен аңа хаклы күрмиләрдер.* Г. Ибраһимов. || Данга, шөһрәткә ия булу, мактау турында. *Безнең бердәм семьябызда [Украина] Данга күмелеп үсә ул.* Ә. Исхак. *Яу булып килә авылга Безнең армия — Җырларда данга күмелгән Кавалерия.* Ф. Кәрим.

10. *күч.* Нинди дә булса хискә, кичерешкә тулысынча бирелү, дучар булу. *[Кайбер язучылар], үзләренең эчке хисләренә күмелеп, форма „нечкәлекләренә" бирелеп, үзләре дә белми формализмга табан баралар.* Һ. Такташ. *Ул әллә нинди уйларга күмелеп, дәшми-тынмый гына барган җиреннән дертләп уянып китә.* Ф. Хөсни. *Ул шатлык дулкынына күмелеп калган иде.* А. Әхмәт.

КҮМГЕЧ *и.* Үсемлекләрнең төбен күмү өчен авыл хуҗалыгы коралы; *русчасы:* тяпка, мотыга.

КҮМЕР *и.* 1. Казып табыла торган, ташка әйләнгән үсемлек калдыгыннан гыйбарәт янучан каты матдә. *Таш күмер. Соры күмер.* □ *Забойлар янында эшчеләр вагонеткаларга күмер төяп, магистраль буйлап этеп алып китәләр.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Күмер чыгаруга мөнәсәбәтле, күмер табу эшләренә мөнәсәбәтле. *Күмер промышленносте. Күмер бассейны.* □ *Ул үзе дә Екатеринослав губернасындагы күмер шахталарында, Каспий диңгезе буендагы балык промыслоларында эшләп йөри.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Күмер чыгару, күмер ташу, күмер саклау өчен билгеләнгән. *Күмер комбайны. Күмер склады.* □ *Клетька күмер вагоннары кертеп маташалар.* Һ. Такташ.

2. Агач янып, көлгә әйләнгәнче сүнгән яки сүндерелгән, кабат ягулык итеп кулланыла торган кара төстәге калдык. *Шәрифҗан тактага күмер белән зур итеп түгәрәк сызды да аның уртасына кара бәрәңге ясап куйды.* И. Гази.— *Самоварга чыра салгансың да, күмер салмый чыгып киткәнсең.* Ш. Мөхәммәдев. || Янып куз хәленә килгән агач кисәге, куз хәлендәге агач кисәге. *Шуннан соң ул, сүрелеп баручы күмер өеменә күзләрен яртылаш йомып караган хәлдә, бер тын дәшми генә утырды.* К. Нәҗми. *Шәйхаттар бабай, тәмәке кабызу өчен мичтән алган күмергә өрүеннән туктап, күзләре белән Мәйсәрәне эзләде.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Күмер саклау өчен билгеләнгән. *Күмер савыты.* || *с. мәгъ.* Агач күмереннән ясалган, агач күмере ярдәмендә эшли торган. *Күмер противогазы. Күмер электрод.*

Күмер кислотасы — углекислый газны суда эретеп ясалган кислота. **Күмер төшү** — утын янып утлы күмергә әйләнү.— *Самоварларга сулар да салмагандыр әле, мичтә күмер төшкәндер инде, салырга кирәк.* М. Гали. **Күмер яндыру** — һаваны аз гына кертеп яисә бөтенләй кертмичә агачны яндыру ысулы белән агач күмере хәзерләү. [*Ул*] *күбрәк урман эшендә: күмер яндыра, сумала кайната яисә сунарга йөри.* Э. Касыймов. **Күмер яндыручы** — агач күмере хәзерләү белән шөгыльләнүче кеше, күмер яндыру белән кәсеп итүче кеше. *Юлда күмер яндыручылар янында кунып, икенче көнне төштән соң [заводка] барып кердек.* М. Гафури.

◇ **Күмер ашау**—кемнең дә булса әле кечкенә бала икәнен белдергәндә әйтелә. [*Зәкия:*] *Сиңа дигән кыз мич буенда күмер ашый ди әле.* Р. Ишморат. **Күмергә әйләнү (калу)** — юкка чыгу, бетү. *Әйдә атлан атыңа, бергә Кертик аларны кабергә, „Аксөяк"ләр ятсын җиргә, Әйләнсен кара күмергә.* Г. Камал. *Яна йөрәк, яна йөрәк, Күмергә кала инде; Йөрәгемнең янулары Гомергә кала инде.* Җыр. **Күмер итү** — күмергә әйләндерү; юк итү, юкка чыгару. *Без торгызган матур сарайларны Җиргә екты, күмер итте ул.* З. Мансур. **Күмер карагы** *иск.*— революциягә кадәр шәкертләрне карагруһчылар шулай атаганнар. [*Карагруһчы — шәкертләргә:*] *Итәкләрегезгә абынып егылмагыз! Һи, күмер караклары!* Г. Камал.

КҮМЕРЛЕ *с.* 1. Күмер төялгән, күмере булган. *Эшчеләр һаман да клетка белән шахтага төшеп тора, күмерле вагонеткалар менеп тора.* Ш. Камал.

2. Күмергә буялган, күмергә пычранган. [*Гөлчирә:*] *Әти, минем кулым күмерле, арбасы белән [баланы] минем янга керт әле.* Т. Гыйззәт.

КҮМЕРЛЕК *и.* 1. Самоварда су кайнату өчен күмер яки башка шундый нәрсә яндыра торган савыт. *Шул тирәдә торучы каравылчы бабайдан --- самовар алып, коры-сары чыбык-чабык белән кайнаталар. Хуш ис, тәмле ис чыксын өчен, күмерлеккә лимон кабыгы ташлыйлар.* И. Рәмиев.

2. Күмер саклый торган урын.

КҮМЕРЛӘНДЕРҮ *ф.* Яндырып күмергә әйләндерү; яндырып чит-читләрен күмер итү. *Шырпыны күмерләндереп, соры стенага ясады матрос Ленин рәсемен.* Г. Гобәй.

КҮМЕРЛӘНҮ *ф.* 1. Янып бөтенләй күмергә әйләнү, күмер булу. *Күмерләнгән өйнең тупсасында Аунап ята ана гәүдәсе.* М. Җәлил. *Хәлим --- яртылаш күмерләнгән агачларга карап бик озак басып торды.* И. Гази. || Нәрсәнең дә булса чит-чите яну, чит-чите көйрәү. *Тик биек моржа белән күмерләнеп кара көйгән баганалар һавага сузылып утырып калалар.* Г. Ибраһимов. *Маратның [коймагы] исә кечерәк тә, яньчек тә, ә берсенең асты күмерләнеп беткән иде.* Г. Гобәй.

2. Агачның һавасыз һәм утсыз таркалуы аркасында күмер (1 мәгъ.) барлыкка килү (ташкүмер турында). *Ташкүмер --- агачларның җир астында һавасыз таркалуыннан һәм күмерләнүеннән барлыкка килгән.* Химия.

КҮМЕРЧЕ *и.* Күмер сатучы, күмер сату эше белән шөгыльләнүче. *Күмерченең — күмере, итекченең итеге юк.* Әйтем. *Әхмәтнең --- хәзер итчеләрнең, утынчыларның, күмерчеләрнең концертларыннан бик яхшы хәбәре бар.* Г. Камал.

КҮМ-КҮК *с. Арт. дәр. к.* күк. *Кайда диңгезләр төтен күк Булып күренәдер күзләргә күм-күк.* Г. Тукай. *Күз төпләре күм-күк, иреннәре Кара күмер булып янганнар.* Һ. Такташ.

КҮМ-КҮМГӘК *с. диал. к.* күм-күк. *Суыктан күм-күмгәк булган Гаделкаюм, --- чанасын өстерәп, „кар тавыннан" төгәрәп кенә төште.* М. Гали. *Кар өстендә хәрәкәтсез ятып, теге кешенең битләре, иреннәре күм-күмгәк булган иде.* И. Гази.

КҮМӘ I *и.* Туку станогының бер детале.

КҮМӘ II *и. диал. этн.* Кечкенә балаларны утыртып яки яткырып йөртү өчен өсте каплаулы, ике көпчәкле, агачтан ясалган бәләкәй арба. *Арба артларына күмәләр таккан уракчылар безне узып китәләр иде.* С. Җәләл.

КҮМӘК *с.* 1. Коллектив белән алып барыла торган. *Ә бит кешеләр ялгыз калып, ачтан үлмәс өчен, Күмәк тормыш җирдә төзиләр.* Һ. Такташ. [*Фәхри*], *кызыл фронтларда йөреп, дошманны сөргәннән соң, авылга кайтып, партия, совет эшләренә кереште, күмәк хуҗалык, авыл хуҗалыгын социализм нигезендә төзү юлында көрәшә башлады.* Г. Нигъмәти. || Коллектив белән бергәләшеп башкарыла; үтәлә торган. *Җәйге кичтә учаклар гөрләшеп яналар, Күмәк эштә кешеләр зур бәхет табалар.* Ә. Ерикәй. *Күмәк уеннарда балаларга ике төркемгә бүленергә туры килсә, --- арадан ике узаман сайлана.* Н. Исәнбәт. || *рәв. мәгъ.* Бергәләп, бергә, бергәләшеп; күмәкләп. *Балыкчылар — бар да колхозчылар, күмәк эшләп тормыш яңарта.* М. Җәлил.

2. Күп санлы, күп. *Күмәк хезмәтчеләр [бал кортлары] барысы да кәрәзгә ташлана.* А. Алиш. || *хәб. функ.* Күп, күбәү. *Алар — күмәк. Мин әле яңа гына килгән берәү булганга күрә, сүзне озынга җибәрергә курыктым.* М. Гафури.— *Күбәләкләр күмәкләр, Биергә шаян кунаклар.* Н. Исәнбәт.

3. *и. мәгъ. сөйл.* Коллектив, нинди дә булса максат белән оешкан кешеләр төркеме. *Шул күмәктә яңа карашлы, яңа уйлы кешеләр туалар.* М. Җәлил. [*Фәхри:*] *Безгә менә шул бүленүләрдән котылырга кирәк, зур күмәк булып, артель булып, машина белән, трактор белән эшләү юлына күчәргә кирәк.* Г. Ибраһимов.

Күмәк договор — *к.* коллектив договор. [*Фазлый:*] *Эш хакын арттыру мәсьәләсе күмәк договорларны яңарту мәсьәләсенә бәйләнгән икәнлеге профсоюз членына мәгълүм булырга тиеш.* Ш. Камал. **Күмәк итү** — уртак итү, гомумиләштерү. *Без колхозга кергәч, Атуарлар һәммәбезнең күмәк ителде.* Һ. Такташ. **Күмәк җыр** — күмәкләп башкарыла торган җыр; хор. *Микрофоннар, барысы да бердән эфирларны --- яңгыратып, бер күмәк җырга кушылды.* Н. Исәнбәт.

КҮМӘКЛЕК *и.* Бергәлек, күмәк эш итү (хезмәттә һ. б.).

Күмәклек исем *лингв.*— бер төрдән булган предметларның барысы өчен уртак исем. *Күмәклек исемнәрнең төрләре.*

КҮМӘКЛӘҮ *ф. сөйл.* Күмәккә әйләнү, күбәю. *Соңыннан, инде ялгыз өй күмәкләнеп авыл хәленә килгәч тә, элек, башта тагылган исем сакланып калган.* Ш. Камал.

КҮМӘКЛӘП *рәв.* Бергәләп, бөтенесе бергә килеш; бергә тупланып. *Егетләр, кызлар, кулга-кул ялгап, кияү белән киленне уртага алалар, күмәкләп җырлап әйләнәләр.* М. Фәйзи.

КҮМӘКЛӘШТЕРҮ *ф.* 1. Күмәк итү, бергә туплау, бергә җыю. *Аннан кошчыкларны бүлешеп алдылар. Бала саен бер кошчык. Балалар һәркайсы үзенекен, яныннан китмичә, саклап утырырга тиеш була иде. Кошчыкларга ялгыз-ялгыз күңелсез иде.— Әйдәгез, күмәкләштерәбез,— диде Фәрит.* Г. Гобәй.

2. Вак крестьян хуҗалыкларын эре социалистик хуҗалыкларга — колхозларга берләштерү. *Илебезне индустияләштерү, шулай ук авыл хуҗалыгын күмәкләштерү нигезендә яңабаштан кору эшендә химия промышленносте зур урын тота.* Ш. Камал.

КҮМӘКЛӘШҮ *ф.* 1. Бергә туплану, бергәләшү, бергә булу; бер оешкан төркем (коллектив) хасил итү. *Күмәкләшкән яу кайтарган.* Мәкаль. [*Бал кортлары*], *көтүләре белән бергәләшеп, җиң сызганып, күмәкләшеп эшкә ашыгалар.* А. Алиш.

2. Вак крестьян хуҗалыклары эре социалистик хуҗалыкларга — колхозларга берләшү. *Авылда күмәкләшү елларында телгә кереп киткән бу яңа сүз колхозчыларның күңелендә шатлык һәм горурлык уята иде.* Г. Әпсәләмов. *Җир колхозга оешкан хезмәт иясе крестьяннарга гомерлеккә беркетелде, һәм алар бу җирдә, күмәкләшеп, бәхетле, таза тормыш төзиләр.* М. Җәлил.

КҮМӘКЧЕЛЕК *и. кит. к.* күмәклек. *Күмәкчелек идеяләре.*

КҮМӘРТӘ *с.* Күмәртәләп сату итү белән бәйләнгән; күмәртәләп сатыла (яки алына) торган. *Күмәртә товарлар.*

КҮМӘРТӘЛӘП *рәв.* Берьюлы күп микъдарда, күпләп; зур партияләр белән (сату яки алу һ. б. турында); *русчасы:* оптом. *Күмәртәләп һәм ваклап сату.* □ *Казый капчыгыннан күмәртәләп-күмәртәләп акча бирә.* Н. Исәнбәт.

КҮМӘЧ *и.* 1. Май, йомырка, шикәр һ. б. ш. кушып әзерләнгән камырдан төрле-төрле формада пешерелгән ашамлык. *Мич күмәчләре солы, борчак, ясмык, арпа, бодай оннарыннан пешерелә. Аларны әче һәм төче камырдан пешерергә мөмкин.* Хал. ашлары. *Мәрхәбә үзенең төенчеген чиште, иң элек кызыл киҗеле ашъяулык, аннан пешкән зур казылык, майлы күмәч, бик зур бодай икмәге алды.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл.* Ак оннан пешерелгән икмәк, ипи. *Табында күгәрчен күзе кебек бодайдан тартып пешерелгән күмәч.* Г. Латыйп.— *Бу бодай оныннан пешерелгән күмәчне, юка телемнәргә кисеп, иң тәмле ризык урынына бүлмә саен, завод саен, палаталар саен өләшеп йөрерләр.* Г. Бәширов.

◇ **Күмәче көлгә төшү** — 1) *к.* балта суга төшү; 2) ялганы тотылып уңайсыз хәлдә калу.

КҮМӘЧЛЕК *с.* Күмәчкә ярый торган; күмәч пешерергә җитә торган. *Күмәчлек он.* || Күмәч алырлык, күмәч алырга җитәрлек. *Күмәчлек акчасы юк-югын. Ләкин куенында бер кыерчык икмәге бар.* Ә. Гази.

КҮМӘЧЛӘП *рәв.* Күмәч белән, [күмәч ашап (чәй эчү һ. б. ш. турында).— *Мин хәзер чәй китертәм, бер-икешәр стакан күмәчләп чәй эчәбез.* Ш. Камал.

КҮМӘЧ-ТӘМӘЧ *җыйг. и.* Күмәч кебек ашамлыклар, төрле күмәчләр (1 мәгъ.).

КҮМӘЧЧЕ *и. иск.* Икмәк, күмәч пешереп сату итүче. [*Хөсәен:*] *Бүген тиреченең Мөхәммәтҗан абзый белән күмәчче Хәйретдин килеп шуны сөйләгәч, җир ярылса, җиргә керерлек булдым.* Ф. Әмирхан.

КҮМҮ *ф.* 1. Җирдә чокыр казып, шул чокырга нәрсәне дә булса салып, өстеннән туфрак белән каплау. *Документларны яндырмаска, әле кирпеч заводы янына илтеп күмәргә булдылар.* И. Гази. [*Әмирхан:*] *Алтыннарыңны бер генә җиргә күмгән булуыңа мин ышанып бетмим.* Ш. Камал. || Җир, туфрак астында калдыру. [*Мансур:*] *Бервакыт дошман танклары минем окоп өстенә килеп зырылдап әйләнделәр, җиргә күмделәр үземне.* Р. Ишморат. *Беркөн иртә белән Габдулла бакчада, аякларын гадәттәгечә туфракка күмеп, бәрәңге чүпли иде.* Ә. Фәйзи. || Пешерү өчен утлы көл эченә салу (мәсәлән, бәрәңгене). *Абый белән без капчыкларыбыздан бәрәңге чыгарабыз да, аны көлгә күмеп, утны болгата-болгата бәрәңге пешкәнен саклап ятабыз.* М. Гали.

2. Үлгән кешенең гәүдәсен кабергә салып, өстен туфрак катламы белән каплау, өстенә туфрак өю; җирләү. *Атылган кешеләрне кайсы вакытта шул стена янына күмәләр, кайсы вакытта таш стена аркылы Казанка елгасына ташлыйлар.* К. Нәҗми. || *с. мәгъ.* Үлгән кешене күмү эшләрен башкаручы, күмү эшләрен оештыручы. *Күмү комиссиясе.* □ [*Гөлсем апа*], *мәетне хәзерләүне карчыкка тапшырып, үзе, кайда икәнен сорашты да, күмү бюросына йөгерде.* Г. Гобәй.

3. *диал.* Үсемлек тирәсендәге туфракны йомшартып, аны сабагы тирәсенә өю. *Кәбестә күмү. Бәрәңге күмү.*

4. Нәрсә белән дә булса каплап, басып китү (су, кар һ. б. белән). *Язгы сулар белән болыннарны күмеп, Идел ята рәхәт тынлык киңлегендә.* Ш. Маннур. *Очкычларны кабул итәр өчен хәзерләнгән аэродромны кар күмеп китте.* А. Алиш. || Нинди дә булса бер әйбер белән өстен ябу, уратып алу. *Арбаның төбеннән корырак көлтәләрне тартып чыгардым да иң элек дер-дер калтыраган картны шулар белән күмеп ташладым.* Г. Ибраһимов. *Көздән үк өйне ярты тиңеннән тирес һәм салам белән күмеп куйганда гына, кышын аз-маз җылы тотыла.* Ш. Камал. || Нәрсәне дә булса каплау, каплап алу; каплап үсү (үсемлекләр, яшеллек һ. б. ш. турында). *Әллә уйлый туган илнең гөл юлларын, Яфрак күмгән, балкып көлгән күл буйларын.* Н. Исәнбәт.

5. *күч. сөйл.* Бик күплән бирү; баету. [*Җәүһәрия:*] *Киявем булган кешене алтын белән ефәккә күмәчәкмен.* Р. Ишморат. [*Хисами:*] *Мин сине акчага күмәрмен һәм шулар өстенә тагы әткәйдән бер имана җир дә бирдертәрмен.* Г. Минский. || *шигъ.* (Шатлыкка, бәхеткә һ. б. ш.) ия итү. *Тик без генә менә җир күкрәген Дан-бәхетләр белән күмәрбез.* Ш. Маннур. *Шатлыкка күмдең бүген син дәткәңне, әнкәңне дә.* С. Хәким.

6. *күч.* Тавыш, шау-шу белән каплап, чолгап алу. *Тышта безнең авылны күмгән әтәчләр музыкасы каршылады.* М. Әмир. || Нинди дә булса тавышны ишетелмәслек итү, көче ягыннан аны узып китү. *Оркестр тавышын күмәрлек көчле свистогын сызгыртып, өряңа буяу белән бизәлгән паровоз чыкты.* К. Нәҗми.

7. *күч.* Бик күплеп сораулар яудыру, бик күп сүзләр әйтү һ. б. ш. турында. *Сораулар белән күмү.* □ [*Шәңгәрәй*] *тик үзе генә таный торган дәфтәрен алды да секретарьны мәсьәләләр белән күмде.* Г. Ибраһимов. [*Муса Нургалине*], *үзенчә яртылаш үзбәкчәләп, сүз белән күмеп ташлады.* Ә. Еники.

8. *күч.* Нинди дә булса эшне, күренешне һ. б. юкка чыгару, бозу, харап итү. [*Өндәмәләр*] *болай язылган: „Халыкка чылбыр коючылар, җиңү тантанасын бик иртә үткәрәсез. Бөек Рус революциясен күмәргә бик иртә тотындыгыз. Революция яши“.* К. Нәҗми. || Кемне дә булса авыр хәлдә калдыру, авыр хәлгә кую. *Ивановны яклап, Бинаров чыкты. --- Ивановның барча гаепләрне өстенә алуын — яшермәвен әйтте. --- Ивановны күмә бит бу юлэр, дип, моның сүзләреннән көлү өзелмәде.* Г. Ибраһимов.

КҮН I *и.* Махсус юл белән эшкәртелгән (иләнгән) хайван тиресе яки шундый тиренең бер кисәге. *Эш нигәдер әтисенеке шикелле шома бармады, я күн җыерылды, я пычак төртелде.* Ә. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Күннән ясалган, күннән тегелгән. *Өстенә ул чорның үзенә хас киемен — кара күн тужурка, башына күн фуражка киеп, кылыч белән наган таккан атасы, иярле атка менеп, ике йөкнең алдыннан бара.* Г. Бәширов. *Ике урам чатында күн сумкалы бер малай газета сатып йөри.* А. Алиш. || *с. мәгъ.* Күн белән тышланган. *Сангурский киң күн диванга җәелеп утырган.* Ш. Усманов. || *с. мәгъ.* Күн эшкәртүгә, күн иләүгә караган, күн иләү эше белән бәйләнгән. *Күн производствосы.* □ *Җәй көне, картның димләве буенча, Төхфәт кирпеч заводыннан картның үзе эшли торган күн заводына күчеп эшли башлады.* Ш. Камал.

КҮН II *и.* Металл акчаның герб төшерелгән ягы. [*Акча*] *ике яклы: аның бардыр иләк һәм күн ягы.* Г. Тукай.

КҮН III *и. иск.* Күннән ясалган борынгы акча.

КҮНДАВЫЛБАЗ *и. иск.* Озынча йомры барабан. *Авазбайның күндавылбаз кагып, ике ягында чалмалы ике малайның быргы кычкыртканы ишетелә.* Н. Исәнбәт.

КҮНДЕРҮ I *ф.* 1. Үтенеп, сорап, нәрсә дә булса эшләргә ризалату. *Кыз үзенекен кылды: атасын, бүген көтүгә барып, айгырны алып кайтырга күндерде.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл.* Өйрәтү, күнектерү. *Менә мондый тинтәкләргә сөйләгез, өйрәтегез. Тазалыкка, чисталыкка күндерегез, әйтегез.* М. Җәлил. || Буйсындыру. *Күнче күнне күндерер.* Әйтем.

КҮНДЕРҮ II *ф. кит. иск.* 1. Нинди дә булса максат белән берәр кая җибәрү.— *Төрекмән ханы илә сугыш башланган, атам мине гаскәр башы кылып, бик күп гаскәр илә сугышка күндерде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Сүзләр белән үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү, сәлам җибәрү. *Әбигә бик күп сәлам күндердем.* Г. Тукай. *Гүзәл Москва, иртән торган саен Сәламемне сиңа күндерәм.* Ә. Ерикәй.

3. *күч. диал.* Ашау. *Балалар калын-калын телемнәрне әләктереп, тоз сиптеләр. Эре-эре ярмалы бәрәңгеләрне күндерергә керештеләр.* М. Әмир.

КҮНДӘМ *с.* Тыңлаучан, карусыз, буйсынучан, кушканны эшли торган. *Мәхәббәттән аңын җуйган егет Кызның күндәм колы шикелле.* М. Җәлил. *Ул бик йомшак табигатьле, килешүчән, күндәм холыклы иде.* Н. Фәттах. | *и мәгъ. Күндәм өндәмсез эшләр.* Әйтем.

КҮНДӘМЛЕК *и.* Күндәм булу, тыңлаучан булу, карусызлык. *Искә төште: --- Аның күндәмлеге, сабырлыгы, әйткән һәрбер сүзне тыңлавы.* М. Гафури.

КҮНЕ *с. иск. к.* күндәм. *Күне кеше „күл яна!“ дигәч тә иләк белән су алып йөгергән, ди.* Н. Исәнбәт.

КҮНЕГҮ *ф.* 1. Нинди дә булса бер эшкә өйрәнү, нинди дә булса бер эшне башкарырга күнекмә алу. *Күнекмәгән эш булганга, ахры, Кул ябышмый ми-*

нем — ялгышам. З. Мансур. *Кыз ат өстенә утыруга күнегә төште.* А. Шамов.

2. Гадәтләнү, ияләшү. *Колхозчылар моңа бер дә гаҗәпләнми, алар аның сөйләнүләренә күнеккәннәр иде.* Г. Әпсәләмов. *Балалар белән яшәп, балалар арасында эшләп күнеккән педагог өчен моның иште той-гылар табигый бер гадәткә әйләнгән иде.* Г. Минский. || Җайлашу, өйрәнеп китү (сизү органнары турында). *Ут яктысыннан чыккан кешеләрнең күзләре тиз үк караңгылыкка күнегеп китә алмау аркасында, алар, сукырлар төслерәк акрын атлап, сөйләнә-сөйләнә, һәркем үз өенә таба юл алып таралдылар.* Ш. Камал.

3. *и. мәгъ.* Нәрсәгә дә булса өйрәнү яки үзенең күнекмәләрен камилләштерү максатыннан чыгып, бе-рәр кеше тарафыннан башкарылган хәрәкәтләр систе-масы, эш. *Гимнастик күнегүләр.* □ *Төрле авырулар вакытында физик күнегүләр эшләү тыела.* Азат хатын.

4. *и. мәгъ. махс.* Өйрәнүчегә, укучыга нинди дә булса күнекмәләрне ныгыту, камилләштерү өчен би-релгән бирем. *Өйгә бирелгән күнегүләр.* □ *Күнегү-ләр дәрестә үткән грамматик материалны үзләш-терү һәм ныгытуда зур роль уйныйлар.* Д. Тумашева.

КҮНЕККӘНЛЕК *и.* Нәрсәгә дә булса күнеккән булу, өйрәнгән булу; өйрәнгәнлек. *Аның винтовканы тотуында да, патроннарны сумкасына тыгуында да ниндидер сәләтлелек, осталык, күнеккәнлек бар иде.* А. Шамов.

КҮНЕКМӘ *и.* Күнегүләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән осталык, сәләт, нәрсәне дә булса эшли белү тәҗрибәсе. *Күп кенә күнекмәләргә һәм иң гади эш кораллары белән эшли белүгә укучылар гаиләдә өй-рәнәләр.* Йорт эшләре. *Бу күнекмәне ныгыту һәм үстерү өчен, шул фигыльләрне катнаштырып, берәр темага кечкенә хикәя яздырырга --- мөмкин.* Д. Ту-машева.

КҮНЕКТЕРҮ *ф.* Нәрсәгә дә булса өйрәтү. *Гөлсем апа балаларын яп-яшьтән эшкә күнектерде.* Г. Го-бәй. || Системалы рәвештә күнегүләр ясап чыныктыру, өйрәтү.— *Кыш көне кар белән ышкыну, салкын су белән юыну кешене салкынга күнектерә.* Т. Гыйззәт. *Якуп урындыгыннан торды да бүлмә буйлап арлы-бирле йөри башлады. „Аякны күнектерәм",— диде ул.* И. Гази.

КҮНЛЕК *и. махс.* Кайбер тропик агачларның кай-рысыннан алына торган саргылт яки кызгылт төстәге хуш исле сумала (чиркәүдә гыйбадәт вакытында ян-дырыла); *к.* ладан.

КҮНЧЕ *и.* Күн иләү белән шөгыльләнүче, күн производствосында эшләүче. *Казан күнчеләре.* □ *Ми-сырда оста тукучылар, күнчеләр һәм башка һөнәр-челәр килеп чыккан.* Бор. зам. тарихы.

КҮНЧЕЛЕК *и.* Күн иләү, күн эшләү производство-сы. *Күнчелектә эшләү.*

КҮНӘ: күнә суы *иск.— к.* терекөмеш. *Бәгъзе бер усал кияүләр балаларга, кәгазьгә төреп, бер тиен-не, күнә суына манып, 20 тиен сурәтендә бирәләр.* Г. Тукай.

КҮНӘК *и.* **1.** *иск.* Турсык, күн савыт. *Тагы ике углан куй тиресеннән ясалган баш күнәк белән шы-бырдап торган кымыз китерделәр.* Г. Газиз.

2. *диал.* Тырыс (каен тузыннан чиләк формасында төрле зурлыкта эшләнгән савыт).

КҮНӘЯК *и.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан игеп үстерелә торган үлән үсемлек, һиндыба; *русчасы:* ци-корий. || Шул үсемлекнең кофега кушу өчен киптә-релгән тамыры.

КҮНҮ *ф.* **1.** Ризалык бирү, риза булу. *Боларның тәкъдимнәренә каршы Мостафа нык каршы тора алмады, күнде.* Ш. Камал. *Аңа бик озак ялынырга туры килде, Җамал әби бик авырлык белән генә күнде.* А. Алиш.

2. Гадәтләнү, ияләшү, күнегү. *Ул мулланың кы-зуына, урынсыз тиргәвенә, --- аны газапка салуына күнгән, гадәтләнгән иде.* Г. Ибраһимов. || Өйрәнү, нинди дә булса күнекмәләргә ия булу. *Инде эшкә күнә башлаган куллар кулга йокмыйлар.* Г. Гобәй. *Биек икән, күнгән аяклар да Сер бирергә теләр төслеләр.* Ш. Маннур. || Җайлашу, өйрәнеп китү (сизү, күрү, ишетү органнары турында). *Урамнар җиде-сигез катлы өйләр тезеп эшләнгән ящикларга охшый. Күз тиз күнә.* Г. Гали.

КҮП *рәв.* **1.** Шактый санда, байтак санда; саны ягыннан ишле; *киресе:* аз. *Газета укыган җиргә агай-әне күп җыела.* К. Нәҗми. *Ишек алдында эш белән йөрүчеләр күп күренә.* М. Гали. | *хәб. функ. Чибәр-ләр күп, Җан сөйгәнем бер генә.* З. Мансур. || *с. мәгъ.* Саны ягыннан шактый булган, ишле санлы. *Ләкин әдәбият укытучыбызның дәресне күңелле итеп алып баруы аркасында күп кенә әсәрләр белән танышырга өлгергән идем.* Г. Камал.

2. Микъдары ягыннан чамадан тыш, микъдары ягыннан гадәттәгедән артык. [*Нәфисә:*] *Быел уңышны күп алырга ниятләнеп торабыз бит.* Г. Бәширов. || Артык; чамадан тыш, тиешеннән артык. *Күп сөй-ләгән кешене бер дә яратмый иде бабай.* Г. Гали. [*Искәндәр Шәрәфкә:*] *Яхшы йөр. Бу якны күп кай-гыртма! Укуыңа кимчелек килер.* М. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Зур, шактый зур (микъдары, күләме һ. б. ш. яклары). *Ләкин аның тәрҗемәчелек продукциясенең иң күп өлешен әдәби тәрҗемәчелек түгел, гади тәрҗемәче-лек алып тора.* М. Гали. *Безгә Булат иптәшнең дә бик күп ярдәме тиде.* М. Җәлил.

3. Озак, шактый озак. *Күпер башы күк томан, Мин бу илдә күп тормам.* Җыр. *Таң атарга күп калмады.* Ә. Еники.

4. Фигыль белдергән эш-хәрәкәтнең, күренешнең чагылыш дәрәҗәсе зурлыгын, интенсивлыгын белдерә. *Кунак, кымыздан авыз итә биреп, ерак җирләрдә бу йортны сагынып күп кайгырганын сөйләде.* Г. Ибраһимов. || Сыйфатлар янында килеп, аларда билгенең артык булуын белдерә. *Зур кешеләр эшлиләр Моннан да күп зуррак гөнаһ.* М. Гафури. *Ул мин сөйләгәнгә караганда бик күп матуррак иде.* А. Шамов. *Тор-мыш юлы кыска булды, дөрес, Иҗат чоры аннан күп кыска.* З. Мансур.

5. күпкә. Озакка, озак вакытка. *Монда үткән бер матур көн Онытылмас күпкә кадәр.* Ш. Маннур. *Ул акчалар да күпкә җитмәде. Акчаның беткәнен сизгәч, Хәсәншаның иң якын күргән дуслары да бе-рәм-берәм ычкына башладылар.* Ш. Мөхәммәдев.

6. *и. мәгъ.* **күпләр.** Күп кешеләр.— *Революция, бик күпләрнең күзен ачып, алдагы бөек көрәшкә халыкны туплады.* Т. Гыйззәт. *Мохтар бабай кебек күпләр әле Үзе дошман бүген үзенә.* Һ. Такташ.

7. *-лы* кушымчасы алган исемнәр алдыннан килә һәм „берничә" яки „саны ягыннан шактый" дигән мәгънәне аңлатып, кушма сүз ясый: *күп атомлы, күп кыллы, күп квартиралы.*

Күп балалы — балалары күп булган, күп балага ия. *Күп балалы гаилә. Күп балалы аналар өчен дәү-ләт пособиесе.* **Күп баскычлы** — күп стадиядән, күп баскычтан (3 мәгъ.) гыйбарәт. *Күп баскычлы сайлау-лар.* **Күп басулы** *а.-х.*— берничә басудан файдалана торган; игеннәрне басудан басуга күчереп чәчүгә ни-гезләнгән, берничә басуны файдалануга нигезләнгән. *Күп басулы чәчү әйләнеше.* □ *Күп басулы киң кыр-ларда --- Яңа тормыш чәчәк атты.* М. Җәлил. **Күп басулылык** *а.-х.*— игеннәрне җиде-сигез басуга чи-ратлаштырып чәчүгә нигезләнгән чәчү әйләнеше.

Күп иҗекле *махс.*— берничә иҗектән гыйбарәт (сүз, шигырь буыны турында). *Күп иҗекле сүз.* **Күп күзәнәкле** — күп санлы күзәнәкләрдән торган. *Күп күзәнәкле организмнарның килеп чыгуы тереклек тарихында аеруча әһәмиятле вакыйга булып тора.* Үтк. зам. сәяхәт. **Күп миллионлы** — саны, микъдары күп миллион булган. *Күп миллионлы совет халкы.* **Күп милләтле** — күп милләттән, халыктан торган; күп милләттән, халыктан гыйбарәт. *Күп милләтле дәүләт.* **Күп мәгънәле** *лингв.*— күп мәгънәгә ия, берничә мәгънәсе булган. **Күп нокта(лар)** *лингв.*— 1) рәттән куелган өч нокта рәвешендәге тыныш билгесе; 2) текстта төшереп калдырылган урынны билгели торган ноктала рәте. **Күп санлы** — кемнәрнең яки нәрсәләрнең дә булса күп саныннан гыйбарәт. *Күп санлы отряд.* □ *Патша хөкүмәте һәм аның күп санлы түрәләре „инородецлар"дан укымышлы кешеләр булдырмас өчен иң хурлыклы чаралар кулланудан да тайчанмаганнар.* Г. Бәширов. **Күп сулы** — 1) суы күп булган (елгалар һ. б. ш. турында). *Күп сулы елга. Күп сулы Идел;* 2) суга бай, яхшы сугарыла торган. *Күп сулы өлкә.* **Күп тавышлы** *муз.*— җыр яки инструменталь әсәрне бер үк вакытта берничә тавыш белән башкаруга бәйләнгән, полифоник. *Шундый күп тавышлы көйнең бер өлеше уйналгач, Тимербулат туктарга уйлаган иде.* К. Нәҗми. **Күп тавышлылык** *муз.*— күп тавышлы булу, полифония. **Күп тармаклы** — берничә яки күп тармак буенча эш алып бара торган. *Күп тармаклы колхоз.* **Күп телле** — берничә телгә бәйләнешле; берничә телдә төзелгән. *Күп телле сүзлек.* **Күп томлы** — күп томнан гыйбарәт. *Күп томлы сүзлек.* **Күп томлык** — күп томнан гыйбарәт басма. **Күп укладлы** *махс.*— берничә укладтан гыйбарәт. *Күп укладлы экономика яшәгән шартларда дәүләт промышленностеның вак товар крестьян хуҗалыгы белән сәүдә элемтәсе котылгысыз --- иде.* КПСС тарихы. **Күп фазалы** *махс.* — берничә яки күп фаза үтә торган.

◇ **Күп(не) белгән** — белемле булган, хәбәрдар булган, күп белемгә ия булган кеше турында. *Күп торганга таянма, күп белгәнгә таян.* Мәкаль. **Күп беләмлек дәгъвасы (чире)** — берәр кешенең үзен белдекле, бик күп беләм дип санавы турында. *Бигрәк тә аның артык иркәләнүләре, мактанчыклыгы һәм бөтен кешедән күп беләмлек дәгъвасында булуы Хөснуллага һич тә ошамый иде.* Ш. Камал. **Күп булса** — иң күп булганда, иң күп дигәндә, иң күп куйганда. *„Безнең аклар" бик озакка чыдый алмас, Бер-ике ай чыдарлар бик күп булса.* Г. Камал. **Күп вакыт(та)** — күпчелек очракта; бик еш. *Күп вакыт аның көне чебешләр янында үтте.* А. Алиш. *Күп вакытта ул анасының эштән кайтуын көтеп ала.* Г. Минский. **Күп дигәндә** — иң күпкә куйганда, иң күп дип санаганда. **Күп сулар агу** — күп вакыт үтү. [*Банаев:*] *Яшермим: ул вакыт мин чехлар яклы идем... Ләкин, әфәндем, аннан бирле күп сулар акты.* Г. Ибраһимов. **Күп сүзле** — күп сөйли торган, сүзе күп булган (кеше). **Күп тә үтми** — озакламый; тиздән. *Шуннан, күп тә үтми, яраланган Гарәфине яңадан авылына кайтарып җибәрәләр.* Г. Әпсәләмов. **Күп тә үтмәде** — *к.* күп тә үтми. *Күп тә үтмәде, мәмләкәтнең терәге булган Җәгъфәрнең гаип булган хәбәре чыкты.* Г. Тукай. **Күп уйлап тормау** — озак уйлап тормыйча, шунда ук, икеләнүсез эш итү турында. *Күп уйлап тормый, агач башына менеп китә.* М. Фәйзи. **Күп чәйнәлгән** — бик күп сөйләнгән, бик күп мәртәбәләр кулланылып, үзенең тәэсирлелеген югалткан (тәгъбир, сүз һ. б.). **Күп яшә** — озын гомер теләүне белдерә; *к.* мең яшә. [*Буран:*] *Рәхмәт, егет, күп яшә!* М. Җәлил. **Күпкә китү** — арту, артып китү, чамадан ашу. *Акчаның саны бик күпкә китә башлады.* М. Гафури. **Күпне куу** — күп нәрсәләргә ия булырга яки нинди дә булса зур максатка ирешергә тырышу. *Күпне куган кешенең эше һич бетмәс.* Мәкаль. **Күпне күргән** — күп кичергән, тәжрибәле, тормыш тәжрибәсе бай булган кеше турында. *Сезгә менә тагын хатлар яза Күпне күргән Такташ бабагыз.* һ. Такташ. **Күпне күрү** — артык ваклыкларга, кирәкмәгән дип саналган нәрсәләргә игътибар итү. [*Рәхимҗан:*] *Күпне күрә, күпне белә торган тынгысыз карт дип алып ташладың син мине.* Р. Ишморат. **Күптән түгел** — әле генә, моннан беркадәр вакыт элек. *Бикмулла бригадасы да күптән түгел генә кайткан булырга охшый.* Г. Бәширов.

КҮ'ПБУЫН *и. мат.* Берничә бербуынның суммасын тәшкил иткән алгебраик аңлатма. *Ньютон биномы формуласы күпбуынны дәрәҗәгә күтәрергә мөмкинлек бирә.* Алгебра.

КҮ'ПБУЫНЛЫ *с.* 1. *мат.* Берничә бербуынның алгебраик суммасыннан торган. *Күпбуынлы алгебраик аңлатма.*

2. *физ., тех.* Буыннары күп булган (җайланма, аппарат һ. б. ш. турында). *Күпбуынлы вал.* □ *Күпбуынлы тезмә ракеталар, К. Э. Циолковский алдан әйткәнчә, хәзер бездә һәм чит илләрдә зур тизлек белән һәм гаять ерак араларга очалар.* Космик ракеталар.

КҮПЕК: күпек балыгы *иск.*— *к.* акула.

КҮПЕР *и.* 1. Елга, чокыр, тимер юл һ. б. ш. аша үтеп йөрү өчен төзелгән корылма. *Тимер юл күпере.* □ *Челтәрле күпер тактасын Җиз дагалы ат таптасын.* Җыр. *Сабир абзый, елга аша яңа агач күпердән чыкканда, су буе тулы казларга игътибар итте.* Ә. Еники. ‖ *күч.* Сөйләнә яки языла торган фикерләр арасындагы логик бәйләнеш, эзлекле күчеш.

2. Су читендә пароходка, паромга керү, көймәләр туктау, кер чайкау өчен такта яки бүрәнәләрдән ясалган корылма, мәйданчык. *Паром туктый торган күпердә, кулына кармак сабы тотып, Салих утыра.* Г. Мөхәммәтшин. *Гажәеп аяз көннең якты кичен мин Кабан күле читенә ясалган бер агач күпер өстендә каршы алдым.* Ф. Әмирхан.

3. Ремонт яки төзү эшләре алып барганда бина стеналары тирәли такталардан ясалган мәйданчык (төзелеш басмасының бер өлеше). *Ул буш вакытларда төзелеш басмаларының иң югары күперенә менәргә, шуннан торып тирә-юньгә карарга ярата.* А. Шамов.

4. *тех.* Автомашинада, тракторда шассиның дифференциалдан ике тәгәрмәчкә көчне күчерү механизмы урнашкан өлеше. *Алгы күпер.* □ *Арткы күпер корпусыннан майны корпус төбендәге магнит бөкеле тишектән агызып алалар.* Тракторлар.

5. *спорт.* Җиңел атлетикада: үкчәләргә һәм учларга (яки башка) таянып, гәүдәне дугаландырып күкрәк ягы белән өскә күтәрелүдән гыйбарәт гимнастик фигура.

6. *махс.* Ясалма тешләрне беркетә торган планка.

7. *анат.* Баш миенең озынча ми белән урта ми арасына урнашкан өлеше. *Озынча мидән югарырак, аңардан ачык рәвештә аркылы буразна белән аерылган күпер ята.* Анатомия.

Күпер сугу *сөйл.*— елга яки чокыр аша күпер салу, күпер төзү.

◇ **Күпер башында күчәр башлары эләгешкән (тәртә очлары орынган)** — бик ерак туганнар яки туган булмаган кешеләр турында.

КҮПЕРЕЛЕП *рәв.* Үсемлек һәм игеннәрнең бик яхшы булып үсүен белдерә. *Төрле матур чәчәкләр җәй саен күперелеп үсәләр.* Ак юл.

КҮПЕРЕНКЕ *с.* 1. Кабарып торган, кабарынкы, күпереп торган. *Аның күперенке иреннәреннән, гажәпсенгән күз карашларыннан, хәтта басып торышыннан да балалык аңкый.* А. Шамов. *Зур көзгедә таралмаган җирән чәчле, күперенке юбкалы бер кыз белән янәшә басып торган Саматов күренә иде.* Г. Әпсәләмов. || Кабарып торган куе (чәч, мыек һ. б. ш. турында). *Менә хәзер дә ул, үзенең дулкынлануын басарга тырышып, күперенке кара мыегын бармак битләре белән сыпырып торды.* Ә. Еники.

2. *күч.* Матур, нәзакәтле дип саналган яки төче сүзләр белән чуарланган; купшы (сөйләм һ. б. ш.). *— Аннары күперенке сүзләр белән маташырга теләк тә юк иде.* А. Шамов. [*Шагыйрьнең*] *сүзләре дә шигырьләре сыман хиссез, күперенке иде.* Х. Сарьян.

КҮПЕРЕНҮ *ф.* 1. Дымнан, җылыдан һ. б. ш. кабару (нинди дә булса масса турында). *Тәрәзәдән яз җылысы белән күперенгән дымлы җир исе, тал бәбчекләренең төчкелт исе бәреп тора иде.* Г. Бәширов. || Күбеккә әйләнеп күтәрелү, кабару. *Күперенгән дулкын.*

2. Кабару, күперү (чәч һ. б. ш. турында). [*Хәят*] *үз-үзләреннән күперенеп тора торган --- чәчләрен тараганда, Лиза дача хәлләрен сөйли торды.* Ф. Әмирхан. [*Атның ялын*], *башкалар кебек, бөтенләй бетертмәдем: бер чирек кадәрлерәк калдырып, үзеннән-үзе күперенеп тора торган иттем, төзәттердем.* Г. Ибраһимов.

3. *күч. сөйл.* Ачулану, ачу кабару. *Олаучым, үлем алдындагы кеше кебек, сулышын еш-еш ала һәм, бәлане миннән күрергә телгәндәй, минуттан минутка миңа сүзсез генә күперенә барган кебек иде.* Ф. Хөсни. [*Фәрхи карчык:*] *Күперенә башласаң, бер дә юкка каз куыгы шикелле күперенсең дә китәсең.* Ш. Камал.

КҮПЕРМӘ *и. к.* күпертмә I (1 мәгъ.). *Гөлҗиһан күпермә иңбашлы, тар билле, киң итәкле алсу асыл күлмәктән иде.* А. Расих.

КҮПЕРТКЕЧ *и.* Йомырка, каймак һ. б. ш. ны күпертү өчен кулланыла торган агач калак, таякчык (күбек пешерү өчен). *Йомырка агы сарысыннан аерып алына һәм агач кашык яки махсус күперткеч белән күпертелә.* Хал. ашлары.

КҮПЕРТМӘ I *и.* 1. Хатын-кыз күлмәге һәм алъяпкычының иңбашларына бер ягын бөреп тегеп куелган һәм аннан канат сыман булып салынып төшкән материя кисәге, өстәмә бизәк. *Бригадир, дулкынланып, толым очын үрергә тотынды да, аны ташлап, алъяпкыч күпертмәләрен төзәтеп куйды.* Г. Бәширов.

2. Хатын-кыз күлмәгендә челтәрдән яки җинел материя кисәгеннән ясалган бөрмә. *Күпертмәле күлмәк.*

КҮПЕРТМӘ II *с. сөйл.* Күпертелгән, арттырылган. *Атласов белән икесе каяндыр алган күпертмә санны* [*аның*] *йөкләмә итеп күрсәтүе Садыйковны тетрәтеп җибәрде.* С. Рафиков.

КҮПЕРТҮ *ф.* 1. Туглый-туглый күбекләндерү, күбеккә әйләндереп кабарту. *Йомырка агын күпертү.* □ [*Чәлпәк пешерү өчен*] *йомырканың сарысын агыннан аерып алып, шикәр комы кушарга һәм агач кашык яки махсус күперткеч белән туглап күпертергә кирәк.* Хал. ашлары. || Күбек сөртү, күбекләндерү. *Ишектән Хәмзә килеп чыга, башын тәмам сабын белән күперткән.* Г. Камал.

2. Көпшәкләндерү, көпшәк хәлгә китерү; кабарту (туфракны һ. б.). *Яңгырый мотор җырлары, Күпертә җирне сабан.* З. Мансур.

3. Кабарту, кабарынкы хәлгә китерү; кабартып чыгару. *Шулай да аңа идәнгә җәелгән саламны калынрак түшәп, кабартып, күпертеп бирделәр.* А. Шамов. *Өй шактый суык иде, юрганнары өстеннән берәр нәрсә алып япты, мендәрләрен күпертте.* Г. Гобәй. *Чалманы мөмкин хәтле күпертеп урады да, аның юри озын калдырылган ягын арттан алып җилкә аша чыгарып куйды.* Ә. Фәйзи.

4. *куч.* Үтә арттыру, күтәрү (бәяләрне). *Үз товарларын күпертелгән бәяләр белән саткан монополияләр шул ук вакытта крестьян хуҗалыкларыннан продуктларны чиктән тыш түбән бәяләр --- [белән] сатып алалар.* Политэкономия.

5. *куч.* Берәр нәрсәне чынбарлыкта булган күләменнән арттырып, чамадан тыш зур итеп күрсәтү. *Байлар, куштаннар, им-томчылар, динчеләр бу фактны күпертеп, аны әллә нинди зур бер хәлгә әйләндерәләр.* М. Җәлил.

Күпертеп чигү — кабартып чигү (чигүнең бер төре).

КҮПЕРЧЕК *и.* 1. *Кеч. форм. к.* күпер (1, 2, 5, 6 мәгъ.).

2. Корабльләрдә, кайбер машиналарда күзәтү, идарә итү өчен калку мәйданчык. *Илдар югарыга, штурвал күперчегенә күтәрелеп карады.* Г. Гобәй. *Югарыда, капитан күперчегендә, порт җитәкчеләре җыелган.* С. Сабиров. || Кайбер а.-х. машиналары янында басып эшләү өчен ясалган калку мәйданчык. *Нәфисә барабан күперчегенә менәргә генә торганда, авыл ягыннан кемнеңдер дөп-дөп ат сикертеп чабып килгәне ишетелде.* Г. Бәширов.

КҮПЕРҮ *ф.* 1. Күбекләнеп кабару, күбекләнеп күтәрелү. *Ул да түгел, күпергән сөт казан капкачын күтәрә.* И. Гази. || Әчүдән күләме зураю, чамадан тыш кабарып чыгу, күтәрелү (камыр, катык һ. б.).

2. Көпшәкләнү, көпшәк хәлгә килү; кабарып йомшару. *Пионерлар сабаннарны тирес астында парланып яткан, җылы кояш нурлары белән күпереп киткән туфракка батырдылар.* Г. Гобәй. || Пешкән вакытта кабару, кабарган хәлгә килү (икмәк һ. б. турында). — *Менә хәзер минем кулда --- күпереп торган, йоп-йомшак, җып-җылы икмәк булса иде.* А. Әхмәт.

3. Кабару, тулылану (тән, яңак һ. б.). *Гарәфи абзыйның маңгай өстендәге чәче коелып беткән булса да, яңаклары бодай кабартмасы кебек күпереп тора.* Г. Әпсәләмов. || *сөйл.* Симерү, тазару; симерүдән тулылану. *Ни өчен берәүләр корсак киерәләр, кабаралар, күперәләр дә, ни сәбәпле икенчеләр ачлыктан каталар, үләләр?* Г. Тукай.

4. Кабару, кабарып тору (чәч һ. б.). [*Илгиз*] *күпереп торган йонлы мех киемнәрдән туп кебек йомры булып күренә.* А. Расих. *Күпереп торган мамык мендәрләрдән --- пакьлек, сафлык аңкып тора.* А. Шамов. || Йоннарын кабарту, тырпайту (мәсәлән, күркә). *Кайсы чакта күперсә дә, тиз шиңә бит теге, ишек алдындагы ата күркә.* Г. Тукай. || (Җил өрүдән) кабару, кабарып чыгу (кием, җилкән һ. б. ш.). *Көннәрнең беренче базар халкы кари әфәндене велосипедка атланган хәлдә күрделәр: аның зәңгәр җөббәсенең киң җиңнәре җил белән күпергәннәр.* Ф. Әмирхан.

5. *күч.* Арту, зураю (гайбәт, хәбәр һ. б.). *Гайбәт, күпергәннән-күперә барып, бистәгә бик тиз таралып өлгерде.* Г. Гобәй.

6. *рәв. мәгъ. сөйл.* **күпереп.** *к.* күперелеп. *Күпереп үскән иген кырларыннан --- Безгә бүген якын дуслар килде.* Ш. Маннур.

КҮПКЫЙММӘТЛЕ *с. мат.* Берничә цифр билгесен эченә алган, берничә цифрдан гыйбарәт. *Күпкыйммәтле сан.*

КҮПКЫЙММӘТЛЕЛЕК *и. мат.* Күпкыйммәтле булу. *Санның күпкыйммәтлелеге.*

КҮПКЫРЛЫ *с.* 1. *махс.* Берничә кыры (ягы) булган, берничә кырдан (яктан) гыйбарәт. *Күпкырлы гайка.*

2. *күч.* Күп төрле тармакларга караган, күп төрле якларны үз эченә алган. *Күпкырлы эшчәнлек. Күпкырлы талант.* □ *— Шахтер җизнине әйтәм, бер яклы гына кеше түгел иде, --- күпкырлы иде.* Г. Галиев.

Күпкырлы почмак *мат.* — бер ноктада кисешүче берничә яссылык тарафыннан барлыкка китерелгән геометрик фигура. *Әгәр күпкырлы почмакның барлык кырларын яссылык белән кистерсәк, кисемдә күппочмак килеп чыга.* Геометрия.

КҮПКЫРЛЫК *и. махс.* Барлык яктан да яссы күппочмаклар белән чикләнгән геометрик җисем. *Күпкырлыкның бер ноктадан чыккан кырлары күпкырлы почмак төзиләр.* Геометрия.

КҮПКЫРЛЫЛЫК *и.* Күпкырлы (2 мәгъ.) булу. *Эшчәнлекнең күпкырлылыгы.*

КҮП-КҮМГӘК *с. сөйл. к.* күм-күк. — *Кәрим яклы булып ялган шаһитлык биргән иярченнәренең йөзләре күп-күмгәк булып, тотараш булып каттылар.* Г. Камал. *Аның ярасы күп-күмгәк булып беленеп торса да, хәзер караңгыда бернәрсә дә күренми иде.* А. Шамов.

КҮПЛЕК *и.* 1. Күп булу; саны ягыннан күп булу. *Бу базарлардагы сатучы-алучының һәм кибетләрнең күплеген күреп, Габделкаюмның исе китте.* М. Гали. || Нәрсәнең дә булса муллыгы, микъдар ягыннан күп булуы, ишле булуы. [*Хәйдәр:*] *Менә без, балалар, бу бакчаның матурлыгына, аның җимешләренең күплегенә сокланып бетә алмыйбыз.* Г. Бәширов.

2. *лингв. к.* күплек саны. [*Хәлим:*] *Берлек белән күплекне бутадың. Кара аны, егет, укытучы ишетеп, үзеңә казык утыртып куймасын.* Г. Гобәй.

Күплек саны *лингв.* — чынбарлыктагы аерым предметларның һәм күренешләрнең ике яки аннан артык булуын белдергән грамматик категория. *Күплек саны уртаклык исемнәр ахырына махсус кушымча ялгау юлы белән белдерелә.* Татар теле грамматикасы.

КҮПЛӘП *рәв.* 1. Бик күп санда яки микъдарда. *Зур язучыларның әсәрләрен күпләп басуны алга куярга кирәк.* М. Җәлил.

2. *махс.* Зур партияләр белән, күп микъдарда (товарларны алу һәм сату турында). *Ул чордагы татар сәүдә буржуазиясе арасында, Москва фабрикантларыннан көтәргә күпләп мал алып, соңыннан „шартлаган" булып банкротлык игълан итү --- бик модадагы әйбер иде.* М. Гали.

КҮПЛӘТӘ *рәв. к.* күплəп (2 мәгъ.). *Ә икенчесе үзенең җире җитәрлек булуы өстенә, 48 дисәтинә җирне чагыштыргысыз арзанга, дисәтинәсен 3,55 сумга күплəтə „сатып ала".* В. И. Ленин.

КҮ'ПМЕ *сор. а.* 1. Предметларның саны, микъдары турындагы сорауны белдерә: никадәр санда, микъдарда? [*Хәкимҗан:*] *Безнең колхозның күпме тавыклары, казлары, үрдәкләре бар икән?* А. Әхмәт. [*Нуретдин:*] *Әнә „Алма"ны алыгыз, нинди яхшы мал бит, хайван! Былтыр күпме сөт бирде әле ул?* Ә. Еники. || *рәв. мәгъ. Ял вакытларында алар үзләре эшләгән җирдән күпме бодай чыгарга тиешлеге, күпмесен фронтка биреп, күпмесен орлыкка калдырырга кирәклеге турында күңелле әңгәмәгә кереп китә торганнар иде.* Г. Бәширов.

2. *сөйл.* Вакыт турындагы сорауны белдерә: никадәр, озакмы? [*Минһаҗ:*] *Чабатадан итеккә күчкәнеңә күпме әле?* К. Тинчурин. | *рәв. мәгъ. Күпме йоклаганмыдыр — белмим, кинәт кемдер мине төрткәли башлады.* Ә. Айдар. *Күпме дәвам иткәндер бу хәл, тик бераздан гына ул үзенә төбәлгән бер пистолет, ике автомат көпшәсен күреп алды.* Ә. Еники.

3. *сөйл.* Ни бәя, ни хак. [*Сафура:*] *Бәяләрен күпме куярсың икән?* Т. Гыйззәт.

4. *рәв. мәгъ.* Гадәттә тойгылы җөмләләр составында килеп, берәр нәрсәнең бик күп санда яисә микъдарда булуын белдерә. *Күпме газап, күпме әрнүләр Без кичердек авыр елларда!* Ә. Исхак. [*Сәфәр:*] *Безнең күпме ачы тир сыгылып салынган ул сабынга!* Ә. Фәйзи. || *Әллә, менә, әнә* кебек сүзләр белән килеп, шул ук мәгънәне белдерә, ләкин мәгънәсе тагын да көчәя төшә. [*Госманов:*] *Йортында әллә күпме тиреләрең бар.* Һ. Такташ. || Күп, бик күп; күп мәртәбә. *Тырышып хезмәт иткән өчен Күпме бүләкләндем мин!* М. Җәлил.

5. Мөнәсәбәтле сүзләр составында бәйләүче чара буларак кулланыла: 1) иярчен тәмамлык җөмләләрдә. *Ләкин ишек төбендәгеләр, кулларына тигән савытта күпме шулпа бар, һәммәсен эчеп бетерергә тырыштылар.* Г. Ибраһимов; 2) иярчен күләм һәм аергыч җөмләләрдә. *Күпме күп укый, шулкадәр күп белә.*

◇ **Күпме дә булса** — беркадәр; беркадәр санда, микъдарда. *Ләкин бу китапта күпме дә булса үзенең катнашы барлыгын ул берәүгә дә әйтмәде.* Ә. Фәйзи. **Күпме кирәк** — 1) җитәрлек дәрәҗәдә, теләгәнчә; кирәк кадәр; 2) бик нык, бик каты (кыйнау һ. б.). *Ала да, колагыннан тотып, уңлап-суллап, күпме кирәк!* А. Шамов.

КҮПМЕ-АЗМЫ *рәв. к.* азмы-күпме. [*Хөснулла:*] *Торган өчен карчыкка күпме-азмы тулиме икән бу карун?* Ш. Камал. *Кайта углым солдаттан Күпме-азмы вакыттан.* Н. Исәнбәт.

КҮПМЕГӘ *сор. а.* 1. Ни хакка, ни бәягә. [*Якуб:*] *Белəсезме, сугышның бер көне күпмегә төшә безгә? 50 миллион сумга!* И. Гази.

2. Никадәр вакытка, никадәргә, озаккамы. — *Я әйт, кызым, күпмегә сиң ялланасың? Елгамы?* М. Җәлил. [*Газиз:*] *Күпмегә мин бу йорттан аерылам?* Ф. Әмирхан.

КҮПМЕДЕР *б -сезлек а.* Билгесез санда, билгесез микъдарда, билгесез күләмдә дигән мәгънәне белдерә. *Күпмедер вакыттан соң, йөзтүбән яткан Мисбахның колагына аяк тавышлары ишетелгәндәй булды.* Г. Әпсәләмов. || *рәв. мәгъ.* Ачык билгеле булмаган вакыт турында. *Мин бу ата-анада ике елмы, күпмедер торгач, әти дә, әни дә икесе берьюлы авырый башлаганнар.* Г. Тукай. *Күпмедер барганнан соң, менә бервакытны алар үз артларында тоташ, каты бер гөрелдәү ишеттеләр.* Ә. Еники.

КҮПМЕДӘН *сор. а.* 1. *к.* күпмегә (1 мәгъ.). — *Күпмедән сатканлыгын хәбәр итсен.* К. Нәҗми.

2. Нинди исәп белән, нинди исәптән. [*Председатель:*] *Син ул бодаеңны күпмедән чәчмәкче буласың соң?* Г. Бәширов.

КҮПМЕЛЕК 1. *и.* Кемнәрнең яки нәрсәләрнең күпме булуы, сан исәбе турында. *Төз атылган ядрә генә --- Дөрес саный күпмелеген Калган дошманның.* Ф. Кәрим.

2. *сор. а. сөйл.* Ни хаклы, ни бәяле; хакы никадәр торган. — *Барлыгы күпмелек нәрсә алдыгыз?* Г. Ибраһимов.

3. *сор. а. сөйл.* Ничә яшьтә, ничә яшьтәге; ничә яшь тулган. *Аның баласы күпмелек?*

КҮПМЕЛӘП *сор. а.* Чама белән әйткәндә күпме, чама белән алганда күпме. — *Кунаклар күпмелəп булыр?* Сөйл.

КҮПМЕШӘР *сор. а.* Ничәшәр, ничәшәрләп (нәрсәне дә булса алганда, бүлгәндә, өләшкәндә һәркайсына күпме әйбер тиюен, бирелүен сорауны белдерә). — *Күпмешәр граната алдылар? — Сигезәр.* И. Гази.

КҮППОЧМАК *и. мат.* Сыныk сызык белән дүрттән артык почмак ясап уратып алынган геометрик фигура. *Охшаш күппочмаклар. Күппочмакның мәйданын табу.*

КҮППОЧМАКЛЫ *с. мат.* Почмаклары дүрттән артык булган. *Күппочмаклы фигура.*

КҮПСЕНҮ *ф.* 1. Берәр нәрсәне яки берәр төрле әшне чамадан тыш күп дип санау, артык дип исәпләү. *Миңлегәл нихәтле саран, ул да налогны күпсенми.* Ш. Камал. [*Бикбулат*] *кызы аласы өстәмә ашлыкны да күпсенгәндәй тоелды.* Г. Бәширов.

2. Кемнең дә булса берәр ягы өстен яки берәр нәрсәсе күп дип санап, аңардан көнләшү, аңарга көнләшеп карау. *Ә Гафият абзагыз? Әллә ул берәүнекеннән дә күпсенмиме? Кая инде күпсенмәү! Гафият булсын да кешенекенә күз челәтмәсен, имеш.* И. Гази. [*Гомәр:*] *Шул Рокыядан гимназияне күпсенеп исең китте бит!* Ф. Әмирхан.

КҮПТЕРМӘ *и.* Борчак, ясмык яки тары онын йомырка, сөт кушып изеп, табага салып пешерелгән ашамлык. *Күптермәнең камыры коймак камырыннан бераз куерак була һәм ул төче камырдан пешерелә.* Хал. ашлары.

КҮПТЕРҮ *ф.* Күләмен зурайту, арттыру, күбендерү (мәсәлән, эчне); кабарту, кабартып чыгару (мәсәлән, тәнне). *Шалкан эч күптерә, талкан бил ныгыта.* Мәкаль. *Аннары этәчләрнең түшләрен күптергәнче кычыткан белән чабып, барысының да канатларын йолкып җибәргәннәр.* М. Гали.

КҮПТЕРҮЧӘН *с.* Күптерә торган. [*Сәмигулла:*] *Чәй, яхшы пешеп җитмәсә, эчне күптерүчән була.* Ф. Әмирхан.

КҮПТИН-КҮП *рәв. иск. к.* күптән-күп. *Болай тикшергән өчен Салахиев ипташкә күптин-күп сәлам.* Г. Ибраһимов. *„Күптин-күп сәламнәр“не дә әйтеп тормастан, --- [ул хат] язып салды.* Г. Гобәй.

КҮПТӘН *рәв.* 1. Моннан күп элек, хәзерге вакыттан күп элек. *Сазлык кипкән, урманны бик күптән инде бөтенләй диярлек кисеп бетергәннәр.* Г. Гали.

2. Әллә кайчаннан бирле, озак вакыт дәвамында. *Чыпчык күптән ашамаган, бик ач иде.* Г. Тукай. *Кәҗәсе, аның юклыгыннан файдаланып, күптән кызыгып йөргән яшь кәбестәләргә кунакка китте.* Һ. Такташ.

Күптән үткән заман *лингв.*— кайбер телләрдә үткән заманның берәр эш-хәлдән элек башкарылган эш яки хәлне белдерә торган аерым бер формасы.

◇ **Күптән шулай кирәк иде** — кемнең дә булса берәр эшен хуплауны, ул эштән канәгать булуны белдерә. [*Закир:*] *Күптән шулай кирәк иде. --- Үз шәкертең белән үзең назланып, тартылып мөгамәлә итәргә, һич гафу ителерлек эш түгел.* Ф. Әмирхан.

КҮПТӘНГЕ *с.* 1. Хәзерге вакыттан күп элек булган, күптән, әллә кайчан булып үткән. *Бу вакытта Гайнижамалның күңеле ераклarга, үзенең башыннан үткән, күптәнге яктылы-караңгылы, шатлыклы-кайгылы хәлләргә карап очадыр иде.* Ш. Камал.

2. Күптәннән килгән, озак вакытлар дәвам иткән; иске. *Күптәнге дуслык.* □ — *Мин моннан үзем китәргә йөри идем, Казанга күчү — ул минем күптәнге хыял.* Ә. Фәйзи. *Ике көн үткәч, чебешләр һәм бәбкәләр бары да чыгып беткәч, Җамал әби күптәнге уен эшкә ашырды.* А. Алиш.

КҮПТӘН-КҮП *рәв. сөйл.* Бик күп. *Халыкларның сәламнәре --- Килеп тора һәр көн күптән-күп.* Ш. Маннур.

КҮПТӘННӘН *рәв. к.* күптән. *Ул шигырьләр бик күптәннән язылган.* Г. Нигъмәти. *Мин дә, ачык йөзләрне бик күптәннән күрмәгәнгә күрә, эчемнән бик шатлана идем.* Г. Тукай.

КҮПТӨРЛЕ *с.* Төрле-төрле, һәртөрле. *Күптөрле буяулар.*

КҮПТӨРЛЕЛЕК *и. кит.* Күп төрле булу. *Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясының күптөрлелеге.*

КҮПЧЕК *и.* Тышы чигелгән яки челтәр тотылган кечкенә мендәр. *Кунак күп ятса, күпчек урланыр.* Мәкаль. [*Зиннәт:*] *Башым куярга бер кечкенә күпчегем дә, каршы чыгып алырга атам-анам да юк.* Г. Бәширов.

КҮПЧЕЛЕК *и.* 1. Кемнәр яки нәрсәләрнең дә булса күп өлеше, күп саны. *Президиумның күпчелеге Якуб тәкъдимен яклады.* И. Гази. *Аның кайбер элеккерәк язган әсәрләрендә аз-маз гарәп, фарсы һәм госманлы сүзләре күренгәләсә дә, ләкин ул сүзләрнең күпчелеге шул әсәр язылганда халыкның сөйләү теленә кергән сүзләр.* М. Гали.

2. *сөйл.* Халык массасы, халык. [*Иргали:*] *Ә сез, милли бердәмлек дигән булып, казахның ярлы күпчелеге өстеннән бер төркем казах солтаннарының һәм байларының камчысын уйнатмакчы буласыз.* Ә. Фәйзи. *Берничә ай эчендә үк ул, еш кына чыгышлар ясау аркасында, күпчелеккә карата шома гына иттереп сөйләргә күнегеп китте.* Ш. Камал.

КҮПЧҮ *ф. сөйл.* Чамадан тыш эчүдән күбекләнеп кабару (камыр, катык турында). *Катык күпчү.*

КҮПЬЕЛЛЫК *с.* 1. Күп еллар дәвам иткән, күп еллар буена барган. *Күпьеллык хезмәт.* □ *Күпьеллык тәҗрибәләргә карағанда, язның иртә килүе, һаваның үзгәреп торуы, хәтта шактый ук салкыннар булып алуы да сабан бодаена һич куркыныч түгел.* Г. Бәширов.

2. *бот.* Берничә яки күп ел яши торган, күп еллар буена үсә торган (үсемлекләр турында). *Күпьеллык үсемлекләр.* □ *Күпьеллык мәкне декоратив үсемлек итеп үстерәләр.* Йорт эшләре.

КҮПЬЯКЛЫ *с. к.* күпкырлы. *Күпьяклы призма.* □ *Иҗтимагый-гуманитар фәннәр өлкәсендәге күпьяклы эшчәнлеге белән культура төзелешенә үзеннән өлеш кертүче мондый милли институтлар Советлар Союзындагы барлык автономияле республикаларда да бар.* И. Надиров.

КҮРГӘЗМӘ *и.* 1. Халыкка күрсәтү өчен берәр җиргә куелган әйберләр, шул әйберләр тупланган урын. *Ул елны анда техника мәктәпләрендә укучы һәвәскәр художникларның иҗатларыннан зур күргәзмә оештырылган иде.* Г. Гобәй. *Күрше Аланбашның Наташа Осиповна Мәскәү күргәзмәсендә үзенә алтын медаль алып биргән бодайны колхоз басуында үстереп барды.* Г. Бәширов.

2. *с. мәгъ.* Бөтен кешегә (халыкка) күрсәтү, бөтен кешене таныштыру өчен оештырылган, бөтен кешегә гыйбрәт булсын өчен оештырылган. *Гимнастларның күргәзмә чыгышлары.* □ [*Комсомолец:*] *Безгә, бу собраниедә карар чыгарып, кулакларга күргәзмә суд ясауны сорарга кирәк!* Һ. Такташ.

3. *сөйл. с. мәгъ. к.* күрсәтмә (2 мәгъ.). *Күргәзмә әсбаплар.*

КҮРГӘЗМӘЛЕ *с. сөйл. к.* күрсәтмәле. *Күргәзмәле дәреслар.*

КҮРГӘЗМӘЛЕЛЕК *и. сөйл. к.* күрсәтмәлелек. *Бу мисал күргәзмәлелек өчен китерелде.* Х. Госман.

КҮРГӘЗМӘ-ХИСАП *с. мәгъ.* Нинди дә булса эшчәнлек турында хисап бирү һәм шул эшчәнлекне халыкка күрсәтү өчен үткәрелгән, оештырылган. *30 ноябрьда үткәрелгән дәүләт сынавы һәм соңрак зур күләмдәге күргәзмә-хисап концерты студиянең үз эшенә йомгак ясавы булды.* М. Җәлил.

КҮРГӘЗҮ *ф. диал. к.* күрсәтү. *Батырның батырлыгын чәй эчеп утырган чагында күргәзеп булмый.* Һ. Такташ. *Бу караш, настроениеләрне ул „Җир*

уллары"ндагы Кабилдә, Газазилдә аеруча тулы күргәзде. Г. Нигъмәти.

КҮРГӘН-БЕЛГӘН *с.* Таныш булган, күреп белгән. *Кайчагында мин, үземнең күргән-белгән төрле әйберләр турында сөйләп, аның дикъкатен җәлеп итәргә тырышам.* Ш. Камал. || *и. мәгъ.* Таныш булган нәрсә; күреп белгән эш-вакыйга. [*Рәис*] *күргән-белгәнне атап, ачык итеп сөйләргә кушты.* Г. Ибраһимов. || *и. мәгъ.* Таныш кеше, күреп белгән кеше, таныш. [*Шәмгун:*] *Анда әлеге үзебезнең күргән-белгәннәр утыра. Минем сүзне аяк астына салып таптамаслар.* А. Шамов.

КҮРГӘНЕ-КҮРМӘГӘНЕ: күргәне-күрмәгәне шул булсын — кемгә дә булса берәр нәрсә биргәндә яисә кемнең дә булса берәр нәрсәгә ия булуыннан үзеңнең канәгатьсезлегеңне белдерү өчен кулланыла: шуннан башка булмасын, иң соңгысы булсын. *Хәлим тапкан бодайны малайның күз алдында себереп алдылар. Әйдә, күргән-күрмәгәннәре шул булсын.* И. Гази.

КҮРЕК I *и. сөйл.* **1.** Матурлык, ямь; чибәрлек, гүзәллек. *Ишектән кергәч күрек уза, түргә менгәч холык уза.* Мәкаль. *Тау артыннан тулган ай күтәрелә башлый. Дөнья вә табигатькә яңа күрек, яңа матурлык арта.* Г. Ибраһимов. [*Таһир:*] *Бозмасын иде мәҗлес күркен акчасы беткән кеше.* Т. Гыйззәт.

2. *тарт. форм.* **күрке.** Берәр күренешнең матурлыгын күрсәтүче яисә тәшкил итүче кеше яки нәрсә турында. *Батыр егет — яу күрке.* Мәкаль. *Агач күрке — яфрак, адәм күрке — чүпрәк.* Мәкаль.— *Д хәзер сүзне мәҗлесебезнең күрке булган өлкән сержант Рәхимовка бирәбез.* А. Шамов.

КҮРЕК II *и. иск.* Мех, йоны калдырылып эшкәртелгән хайван тиресе. *Күрек кигән күркәм булыр.* Мәкаль.

КҮРЕК III *и.* Һава өрдерү өчен җайланма (тимерчелектә, пыяла производствосында һ. б. урыннарда кулланыла). *Гапсаттар, күрек сабын тирбәтеп, сүнә башлаган горнада алтын очкыннар уйната башлады.* И. Гази. *Түрдә учак. Минһаҗ аны, чыж-чыж иттереп, зур күрек белән очкыннар очырта-очырта өрдерә.* Каз. утл. || Кайбер уен коралларында, һава ярдәмендә музыкаль тавыш барлыкка китерү өчен, тартылып сузыла торган сырлардан гыйбарәт җайланма. *Гармонь күреге.*

КҮРЕКЛЕ *с. сөйл.* Матур, гүзәл. *Зәвык белән тегелгән костюмның күкрәк турысыннан ак ефәк кофточка өстеннән сузылып төшкән кызыл галстук кызның күрекле йөзенә матур җитдилек биргән.* К. Тинчурин. *Шулай да күрекле егет —зур теплоход капитаны дәдуллин Зәйтүнә күңеленнән бөтенләй юк булмады.* С. Сабиров. | *и. мәгъ. Күреклегә күмер кабы да килешә.* Мәкаль.

КҮРЕКСЕЗ *с. сөйл.* Матур булмаган, матур түгел, ямьсез. [*Кыш*] *Елгаларны япты, бикләде, Дулкыннарны итте иректсез, Чишмәләрнең юлын чикләде, Болыннарны итте күрексез.* М. Җәлил. | *и. мәгъ. Күрексез бизәнер.* Әйтем.

КҮРЕКЧЕ *и. иск.* Мехчы, мех эшкәртүче яки мех белән сәүдә итүче. *Төлке никадәр качса да, барыр җире күрекче кибетендәдер.* Мәкаль.

КҮРЕ'ЛМӘГӘН 1. Сыйфат фигыльнең юклык формасы.

2. *с. мәгъ.* Элек очрамаган; искиткеч, гадәттән тыш булган. *Аның көтүлекләрендә моңа кадәр күрелмәгән яхшы нәселле эре терлекләр барлыкка килде.* Г. Бәширов. *Тургайлары җырга нинди әвәс әнә, Моңарчы һич күрелмәгән ягымлылык, Гүзәллек бар һәр нәрсәдә!* З. Мансур.

КҮРЕМ *и.* Җенси яктан өлгергән хатын-кызларда аналыктан ай саен кан килү; айлык, менструация.

КҮРЕМЛЕК *и. сөйл.* Күрер, карар өчен куелган нәрсә (күбрәк ашамлыклар турында). *Туемлык түгел, күремлек.* Әйтем.

КҮРЕМЛӘҮ *ф. сөйл.* Багу, күрәзәлек итү. [*Мулла:*] *Агай садаканы бер тиенләп кенә суза, әллә без өшкерү, күремләү эшенә чыгыйкмы икән?* Әкият.

КҮРЕМСЕЗ *с. диал.* Көнләшүдән күрәлмаучы, нәфрәт белән караучы.

КҮРЕМСЕЗЛӘНҮ *ф. диал.* Кемне дә булса көнләшү җирлегендә күрәлмау, кемгә дә булса карата нәфрәт хисе кичерү. *Аның ярсуына көчсез ирләр көчле, нык кешеләрне очраткач була торган күремсезләнү, нәфрәт күшылды.* А. Гыйләҗев.

КҮРЕМЧЕ *и. иск.* Багучы, күрәзәче. *Күремчегә барма, башыңа кайгы алма.* Әйтем.

КҮРЕМЧЕЛЕК *и. к.* күрәзәлек (1 мәгъ.). *Ялкау мескен зур ялган күремчелеккә бирелә, Күремчелеккә бирелгән кеше үз эшенә иренә.* Я. Емельянов.

КҮРЕНГЕЧ *и. иск.* Билет. *Без тиз генә бардык та, ике тәңкә егермешәр тиенгә күренгечләр алып,* [*поездга*] *утырдык.* Шура.

КҮРЕНДЕК *и. этн.* Кияү кыз куенына кергән вакытта, беренче мәртәбә күрешкәндә, кызга кияү тарафыннан бирелә торган акча яки бүләк. [*Җиңги кияүгә:*] *Күрендеген бирегез.* М. Фәйзи.

КҮРЕНЕКЛЕ *с.* **1.** Атаклы, танылган, дан казанган. *Күренекле фән эшлеклесе.* □ *Шагыйрь Мәҗит Гафури — Бөек Октябрь социалистик революциясенә чаклы булган татар әдәбиятының күренекле вәкилләреннән берсе.* М. Җәлил.

2. Әһәмиятле, мөһим. *Бу әсәрдәге Хафиз, Хафиза һәм Кәрим типлары аның революциядән соң язылган сәхнә әсәрләрендә яхшы эшләнгән күренекле образлар булып торалар.* М. Гали.

3. *диал.* Күренеп торган, күзгә бәрелеп торган. *Күз алдында, күренекле урында зур такта тора.* Һ. Такташ. || Ихтирам ияләре, хөрмәтле кешеләр өчен билгеләнгән. *Иң күренекле урында поплар белән муллалар* [*утыра*], *алар тирәсендә, аягүрә басып, рус, татар, мукшы авыл байлары* [*тора*]. Г. Ибраһимов.

КҮРЕНЕКСЕЗ *с.* Танылмаган, билгеле булмаган; әһәмиятсез.

КҮРЕНЕШ *и.* **1.** Күренү, күренеп тору рәвеше. *Хәсән каралган җәймәсенең читләрен күренмәслек итеп одеял белән каплады да кроватеның читтән күренешен карар өчен өч-дүрт адым артка чикте.* Ф. Әмирхан. || Тышкы кыяфәт, тышкы төс; рухи халәтнең йөздә, кыяфәттә чагылышы, нәрсәнең дә булса тышкы чагылышы. *Чөнки болар кешене киеменә һәм тышкы күренешенә карап хөкем кылалар.* Ш. Мөхәммәдев. [*Галимә апаның*] *шул вакыттагы күренеше безнең барыбызга да тәэсир итте.* М. Гафури.

2. Күз белән күзәтелә торган тамаша; табигать картинасы. *Җәй көне шәһәр ягындагы тау өстә бакчасыннан караганда, каршыдагы түбән якта искиткеч матур, иксез-чиксез бер күренеш ачыла.* Ш. Камал. *Тирә-яктагы күренешкә хәйран калдым. Зәңгәр күл диңгез кебек җәелеп ята.* Г. Ибраһимов. || Табигать картиналарының рәсеме, пейзаж. *Абыйсы аңа конвертка салып Ерак Көнчыгыш күренешләре җибәргән.* А. Әхмәт.

3. Нинди дә булса көчләрнең, эш-хәрәкәтләрнең чагылышы, гәүдәләнеше. *Эрозия күренеше.* □ *Бозның эрүе, суның кайнавы, ташның төшүе, ток узганда чыбыкның җылынуы, җил исү, яшен яшьнәү — табигатьнең төрле күренешләре.* Физика. *Патша хөкүмәте милли культураның һәртөрле күренешен буарга омтылды.* М. Гали. || Нинди дә булса эшчәнлекнең нәтиҗәсе. *Татар операсы илебездәге бөтен милләт халыкларының дуслыгы, туганлыгы, бердәмлеге нуге-*

зендә, шул туганлыкның чәчәк ату күренеше булып барлыкка килде. М. Җәлил.

4. Вакыйга, хәл, факт, берәр очрак. *Кавидә дә иске тормышны, ямьсез күренешләрне язганда искегә нәфрәт, аннан көлү, аның зарарына каршы агитация ясау юк түгел.* Г. Нигъмәти. *Патруль өчен тыныч көннәрнең гади күренешләре генә болар.* Г. Минский.

5. *әд.* Пьесадагы, спектакльдәге актның (пәрдәнең) яки картинаның бер үк катнашучылар тарафыннан уйнала торган өлеше (әлегрәк „мәҗлес“ дип йөртелгән; кайбер язучылар, мәсәлән Т. Гыйззәт, картинаны да — драматик әсәрнең яңа декорация таләп иткән өлешен дә — күренеш дип атый). *„Безнең шәһәрнең серләре“ндәге биш күренеш арасында үзенең художество ягыннан эшләнүе һәм мастерларча бирелүе белән „Печән базары“ күренеше, һичшиксез, иң югары урынны тота.* М. Гали.

6. *этн. к.* күрендек. *Кияү белән кыз күрешә дә, [кияү] кызның кулына акча сала; моны күренеш диләр. Ул бирелгән акчаны яки затны күренеш акчасы диләр.* К. Насыйри.

7. *лингв. иск.* Төр, төр категориясе (рус тел белемендә „вид“ дип йөртелә). *Телебездә мәгълүм бер төрдәге теләсә нинди фигыльләрдән, үзенә аерым фигыльләр кушып, фигыль күренешләре (виды) ясау бар.* Г. Алпаров.

КҮРЕНЕШСЕЗ *с. сөйл.* Кыяфәте матур булмаган, ямьсез, шыксыз.— *Бай кызларына күренешсез генә, нәсел-нәсәпсез генә кавалер белән лихачка утырып йөрү килешми.* Ф. Әмирхан.

КҮРЕНМӘ *с. махс.* Күренә торган, күреп була торган. *Планеталарның күренмә юллары.* □ *Борынгы вакытта кешеләргә яктырткычларның күренмә хәрәкәтләре, мәсәлән, аларның калкуы һәм батуы мәгълүм булган.* Астрономия.

КҮРЕНҮ *ф.* 1. Күз белән кабул ителү, карап сизелү, танылу, караганда күзгә ташлану, күзгә чалыну. *Бөтен тирә-якка ямь сибеп утырган алсу-көрән мәк чәчәкләре уртасында --- яшелле-кызыллы-сарылы чәчәкләр тавы күренде.* М. Әмир. *Караңгылык эчендә таш өстәлләрдә ачып куелган калын китаплар күренә.* Н. Исәнбәт. || Очрау, күзгә чалыну; табылу. [*Язучының*] *урыны белән [Гейненың] стилистик чараларын куллануы да күренгәли.* Г. Нигъмәти.

2. Килеп чыгу, килеп чыгып күзгә ташлану. *Шул арада Зөя елгасы Иделгә кушылган җирдәге борылыштан агып килә торган зур бер сал күренде.* М. Гали. *Юл ачыла дип көтеп торганда, күрше тыкрыклардан, сабан туена ашыккан кебек, кустарълар, шәкертләр, Печән базарының эреле-ваклы кибетчеләре күренде.* К. Нәҗми. || Дөньяга чыгу, басылу (әсәрләр турында). *Гафурның [Коләхметовның] хәзергәчә матбугатта күренгән оригиналь әдәби әсәрләре шулар булып, моннан башка аның „дбүҗәһел“ дигән пьесасы басылып ятканда --- полиция тарафыннан [конфискацияләнгән] булган.* Г. Нигъмәти.

3. Билгеле бер ягы, сыйфаты белән аерылып тору, күзгә ташлану. *Борисов яткан урынынан торып утырды, аның матур чыраенда ризасызлык билгесе күренде.* Г. Бәширов. || Сизелү, тоелу. *Ире аңа элек каты күңелле кеше кебек күренә иде.* Г. Ибраһимов. *Галинең елмаюы да яшерен мәгънәле вә серле шикелле күренде.* Ф. Әмирхан.

4. Нинди дә булса бер кыяфәткә, күренешкә ия булу; нинди дә булса тәэсир калдыру. *Кояш инде түбән булып, төсе кызыл, кояшлы шактый зур күренә иде.* Ш. Камал. [*Гөлбикә:*] *Кызым, һич тайчанмыйча авыл эшләре эшләп йөреп, безгә фирештә кебек күренәсең.* М. Фәйзи. — *Син миңа, бәгърем, матур гөл чәчкәседәй күренәсең.* Ф. Бурнаш.

5. Тормышка ашу, нәтиҗәле булу; берәр нәрсәнең йогынтысы, тәэсире булу. *Шихрай, Фәтхинең киңәше буенча, райпрокурорга Нәгыйлмне ныграк кысу кирәклекне әйткән булса да, аның нәтиҗәсе күренмәде.* Ш. Камал. [*Гариф:*] *Алай дип әйтмә, агай-энеләрнең шундый вакытларда да файдалары күренмәгәч, ни эшкә ярый.* М. Гафури.

6. *з-сыз. хәб. функ.* **күренә (ки), күренеп тора(ки)**— аңлашыла, сизелеп тора. *Күренә, бер бәрәңгедә генә үсмәгән бу кыз, авыр кара эш аны аркылыга җәймәгән.* Ә. Еники. *Күренеп тора ки, [агайның] безгә баш аласы килә, әмма кызның карашында әллә нинди бер илтифатсызлык сизелә.* Ф. Әмирхан.

КҮРЕНҮЧӘНЛЕК *и. махс.* Берәр нәрсәнең күренү үзлеге, күренү мөмкинлеге. *Атмосфераның күренүчәнлеге.*

КҮРЕШҮ *ф.* 1. Очрашкан вакытта исәнләшү, сәламләү йөзеннән кемнең дә булса кулын бер яки ике кул белән кысу. *Сәхипҗамал әүвәл майлы кулын суза, соңыннан сизеп, кулын алъяпкычына сөртеп күрешә.* А. Әхмәт. *Хезмәтенә килгәч иртән торып, Иптәш белән иптәш күрешә.* Ш. Маннур. || Очрашканда нинди дә булса ишарә, хәрәкәт белән исәнләшү. *„Без, рус гадәте буенча, үбешеп күрештек.* И. Гази. [*Мәрфуга:*] *Күз очыннан гына күрештек.* Ш. Камал. || Кем белән дә булса беренче мәртәбә очрашкан вакытта танышу йөзеннән аның кулын кысу. [*Низамый:*] *Зөләл туташ булыр бу безнең, я әле, күрешегез әле.* М. Әмир.

2. Аерылган, киткән вакытта саубуллашу йөзеннән кемнең дә булса кулын бер яки ике кул белән кысу. *Икенче көнне Йосыф, җыенып, якын иптәшләре белән генә күрешеп, кечкенә сандыгын күтәреп китеп тә барды.* Ә. Фәйзи. *Китүчеләр белән озатучылар арасында күрешүләр, сөйләшүләр, ашыгып бер-берсен эзләүләр, бүләкләр бирешүләр китте.* М. Гафури.

3. Очрашу, бергә туры килү, бергә булу. *Айлар, еллар үтте, алар күрешә алмадылар, тик бетмәстөкәнмәс хатлар белән генә юаныштылар.* Г. Ибраһимов. *Сау булыгыз инде, Сау булыгыз, Күрешмәбез, шаян этләрем. Инде моннан соң сез, туры килсә, Таламагыз шәһәр кешеләрен.* Һ. Такташ. || Гашыйклар турында. [*Кызлар:*] *Юк йомышын бар итеп, Тагын киләм дидеме? Аулак җирдә күрешергә Сиңа вәгъдә бирдеме?* Т. Гыйззәт. *Тик менә вакыттан алда баручы кыз белән күрешергә соңга калуы гына күңелсез булды аңа.* Г. Минский. || Больницада, ябык уку йортында, төрмәдә һ. б. ш. урыннарда булган кеше белән очрашу, аны күрү. — *Саттаровның әнисе күрешергә рөхсәт сорый.* А. Шамов. *Төрмәгә барып Хисами белән күрешергә рөхсәт кәгазе бирелсә икән, дип ялваргач, [офицер:] „Бирелмәс“, — диде.* К. Нәҗми.

КҮРКӘ I *и.* 1. Фазаннар семьялыгыннан ит өчен үрчетелә торган зур йорт кошы. *Ата күркә. Ана күркә.* □ *Казын да, үрдәген дә, күркәсен дә Мөдәррис картның миннән бер-ике яшькә кечкенә кызы --- Нәсимә бага.* Ә. Айдар. || *с. мәгъ.* Күркәгә бәйләнешле, күркә белән сату итүгә бәйләнешле. *Менә шул Минзәлә күркә базарында танышканнан бирле Ает бай Габденнасыйрны Шырдан Хөсәен малае дип кенә атап йөртә иде.* М. Гали.

2. Азык буларак шул кошның ите. *Аның майлары тулышып торган ике симез казы белән симез күркәсе, өстенә каклар, җимешләр сибеп пешерелгән зур ләвәш күмәче, --- тагы әллә ничаклы оста әзерләнгән аш бүләкләре мәҗлеснең күзләрен уйнаттылар.* Г. Ибраһимов.

◇ **Күркәдәй кабарыну, күркә кебек (төсле) кабарыну (кукраю)** — масаю, эреләнү. *Элекке генераллар алтын ялтыравыгы белән күзне камаштыра, таштан койган салкын чырае, ата күркәдәй кабаланган.* Ф. Бурнаш.

рынган кыяфәте белән тыныңны куыра иде. Г. Бәширов. [*Хәлим:*] *Хурланып үләрсең кыланышыннан, күркә кебек нинди кабарынып утырган була.* И. Гази. [*Нургали*] *Шәйдуллиннан күркә төсле кукраеп, югарыдан түбәнгә карап сөйләүне көтмәгән иде.* Ә. Еники.

КҮРКӘ II *и.* Ылыслы агачларның тәңкәчекләр белән капланган, гадәттә озынча түгәрәк яисә йомырка сыман булып укмашып үскән орлык чәкәне яки кәшәнкәсе. *Чыршы күркәсе. Нарат күркәсе.* □ *Чернозубов президиум өстәленә эрбет күркәләре китереп куйды.* Ә. Маликов.

КҮРКӘМ *с.* 1. Күзгә матур күренә торган, үзенең матурлыгы, гармониялелеге белән аерылып торган. *Исемнәрең Шәриф, йөзең күркәм, Исем шәрифләрең кем куйган.* Җыр. *Көлемсерәп көн башланды Җәйге күркәм таң белән.* Дәрдмәнд. || Чибәр, тышкы кыяфәте матур (кеше турында). *Иркәм минем бик күркәм, Яратмый дип юк үпкәм.* М. Җәлил.

2. Уңай сыйфатларга яки яхшы үзлекләргә ия, хуплауга лаеклы, әйбәт дип санала торган. *Күркәм холык.* □ *Ул моны, көндезен эшләп шактый нык арыган булуына карамастан, бик чыдам һәм бик күркәм намуслылык белән эшләде.* Ш. Камал. || *рәв. мәгъ.* Яхшы, шәп. [*Галәк бабай:*] *Колхозыбызның* [*эше*] *- - - бик күркәм бара.* Г. Әпсәләмов. [*Ишан:*] *Китап киңәш белән эш күргәнне күркәм таба.* К. Тинчурин.

Күркәм итү — 1) матур күрсәтү, матурайту; 2) яхшы итү, шәп итү. [*Бәдри:*] *Күркәм итеп тәмамларга насыйп булсын.* М. Фәйзи; 3) күнелле итү. — *Ә килә чәкне күрү, шуны күрәм дип эш итү — иң авыр минутларны да җиңел һәм күркәм итә.* Г. Кутуй.

КҮРКӘМЛЕК *и.* Күркәм булу, матур булу, матурлык. *Игелек турылыкта, күркәмлек холыкта.* Мәкаль. *Тегендә табигать күркәмлеге, табигать көче—патша, биредә кеше күркәмлеге, - - - кеше хезмәтенең, меңләгән Газинурлар хезмәтенең тантанасы шаулый.* Г. Әпсәләмов.

КҮРКӘМЛӘНҮ *ф.* Күркәмгә әйләнү, матурлану, чибәрләнү. *Якуб, мәсәлән, образ буларак башта игътибарны җәлеп итмәсә дә, соңрак байый һәм күркәмләнә бара.* И. Нуруллин.

КҮРКӘМЛӘҮ *ф.* Матурлау, чибәрләү. *Соңгы еллар практикасы шул бәйрәмнәрне күркәмли, әхтәлекләрәк итә.* З. Нури.

КҮРМЕШ: күрмешне күрү *сөйл.* — авырлык, кыенлык кичерү. [*Ирхәм:*] *Менә мин сезне җир астында бер ай гына забойщик итеп эшләтер идем, күрер идегез күрмешегезне.* М. Гали.

КҮРМИ: күрми сабак *иск.*—күнелдән ятлый торган сабак. [*Гомәр:*] *Җәгърафия дә укытмыйлар, туган телне дә. Гел күрми сабак кына.* Г. Бәширов.

КҮРМӘГӘН *с. мәгъ.* Моңа кадәр булмаган, күрелмәгән. *Бу 20 ел татар сәнгатендә моңарчы татар тарихында һичвакытта күрмәгән искиткеч үсү, алга китү һәм җиңүләрне китерде.* М. Җәлил.

КҮРМӘГӘН-ИШЕТМӘГӘН *с.* Таныш түгел, таныш булмаган; чит, ят.

КҮРМӘМЕШКӘ: күрмәмешкә салыну (салышу) — берәр нәрсәне яки кешене күреп тә, күрмәгәнгә салыну, үзенне аны күрмәгән кебек тоту. *Газинур да, аннан бигрәк Миңнурый да моны сизеп тордылар, ләкин күрмәмешкә салындылар.* Г. Әпсәләмов. *Әт исә ыкмәкне күрмәмешкә салышып утыра бирде.* Г. Гобәй.

КҮРМӘСЛӘНДЕРҮ *ф.* Күрмәс хәлгә китерү. *Күзләрне күрмәсләндерү.*

КҮРПӘ *и. иск., диал. к.* көрпә I.

КҮРСӘТЕЛЕШ *и.* Художество әсәрендә сурәтләнү, тасвирлану. *Бу тойгыларның характерлы күрсәтелеше „Диңгездә" хикәясендә очрый.* Г. Нигъмәти.

КҮРСӘТКЕЧ *и.* 1. Берәр нәрсә үсешенең, барышының чагылышы, шул үсеш-үзгәреш темпын, күләмен күрсәткән билге, сыйфат. *Социалистик ярыш күрсәткечләре.* □ *Игенчелектә капитализмның төп билгесе һәм күрсәткече — яллы хезмәт.* В. И. Ленин.

2. Берәр кеше, коллектив хезмәтенең, эш нәтиҗәләренең цифрларда, график сызымнарда чагылышы. *Әхмәт витринадан Рамазановның еллык планны үтәү күрсәткечен блокнотына күчереп алды.* Г. Минский.

3. Нәрсәне дә булса күрсәтү өчен хезмәт итүче предмет (юнәлеш угы, кечкенә маяк һ. б.). | *с. мәгъ. Ике юл чатындагы күрсәткеч баганага аркылы-торкылы кадакланган ике такта кисәге кемгә кая китәргә кирәклекне әйтеп торалар.* Ш. Камал.

4. Белешмә китап яки китаптагы белешмә исемлек. *Библиографик күрсәткеч. Исемнәр күрсәткече,* □ *Библиографиянең ахырында төрле басмаларга сүз башы, кереш һәм соңгы сүз язган кешеләрнең алфавит күрсәткече бирелде.* Ә. Кәримуллин.

5. *тех.* Нәрсәне дә булса күрсәтә торган деталь; приборның угы. *Приборның күрсәткече тизлекнең артуын яки кимүен күрсәтеп, күтәрелеп яки төшеп йөргәндә, аңа беркетелгән каләм дә күтәрелә.* Физика. || *с. мәгъ.* Нинди дә булса күренешне күрсәтә, билгели торган. *Күрсәткеч үк.*

6. *мат.* Бирелгән санны яки аңлатманы нинди дәрәҗәгә күтәрүне белдерә торган цифр яки хәреф. *Дәрәҗә күрсәткече.*

Күрсәткеч таягы — нәрсәне дә булса күрсәтү өчен хезмәт итә торган таяк. *Әлтафи карта янына барып басты, күрсәткеч таягын алып, аны Канадага төртте дә сөйли үк башлады.* М. Мәһдиев.

КҮРСӘТМӘ *и.* 1. Теге яки бу очракта ничек эш итәргә кирәклекне өйрәткән киңәш, аңлатма. *Күрсәтмәләр бирү.*

2. *с. мәгъ.* Күрсәтмәләлек өчен хезмәт итә торган. *Күрсәтмә әсбаплар.*

КҮРСӘТМӘЛЕ *с.* Өйрәнелә торган предметларны, аларның модельләрен, схемаларын күрсәтүгә нигезләнгән. *Күрсәтмәле укыту.* □ *Күрсәтмәле агитация чараларыннан киң файдаланылды.* КПСС тарихы.

КҮРСӘТМӘЛЕЛЕК *и.* Өйрәнелә торган предметларны, аларның модельләрен, схемаларын күрсәтүгә нигезләнгән метод.

КҮРСӘТҮ *ф.* 1. Күренә торган хәлгә китерү, карап күрергә мөмкинлек бирү; карап күрергә тәкъдим итү. *Ул кесәсеннән бөгәрләнеп беткән дәфтәр сыман бернәрсә чыгарды да, аннан озак эзләнә торгач нидер табып, Нәфисәгә күрсәтте.* Г. Бәширов. *Күз яшьләрен күрсәтмәс өчен Газинур тиз генә читкә борылды.* Г. Әпсәләмов. || Карап күрергә бирү, тәкъдим итү (документларны һ. б. ш.). [*Малай:*] *Дәй, бабай, бабай, үземнең шатлыгымны уртаклашасым килеп, мин сиңа тулы булмаган урта мәктәп бетергәнлек турындагы таныклыгымны күрсәтеп маташам тагын.* М. Гали. *Шәрәфи әгъзалык билетын күрсәткәч, ишек ике якка аерылды.* Г. Ибраһимов. || Кешеләр карап күрсен өчен берәр эш-хәрәкәт башкару, нәрсәне дә булса демонстрацияләү. *Кино күрсәтү. Фокус күрсәтү.* □ *Театр берничә классик опера һәм балетлар күрсәтте.* М. Җәлил. || Кемне дә булса тиешле аңлатмалар биреп таныштыру. [*Әткәй:*] *Ә менә бусы — оста Зариф бабаңның төпчеге, — дип, таза, калын, сабыр малайга күрсәтте.* Г. Ибраһимов. *Илсояр будка түбәсендә рота командирына тирә-яктагы авылларны күрсәтә-күрсәтә нидер сөйләп торган Өметбаевтан да шул турыда сорады.* Г. Гобәй.

2. Хәрәкәт, ишарә белән кемнең дә булса игътибарын берәр кешегә яки берәр нәрсәгә юнәлдерү. *Малайлар ул күрсәткән якка таба карадылар: атка*

атланган биш кеше туп-туры сукачылар янына чабышып киләләр. И. Гази. || Тәкъдим итү. [*Соловьев*], *кәгазьләрен бер читкә этәреп, Газинурга урын күрсәтте.* Г. Әпсәләмов. || *и. мәгъ. сөйл.* Күрсәтмә. [*Мостафа:*] *Мондый эшләр Цеканың күрсәтүе буенча эшләнә.* Ш. Камал.

3. Нинди дә булса бер формада, рәвештә яки хәлдә итеп күрергә ярдәм итү. [*Закир шешәләргә:*] *Сез минем күзгә Гайнине матур итеп күрсәттегез.* Г. Камал. *Ул бит аны шул ук өч кешегә дигән әйбердән пешерде, ә куе күрсәтү өчен, өйрә булса, изелгәнче кайнатты.* Г. Гобәй.

4. Кешеләргә нинди дә булса хисне, үзеңнең сыйфатыңны, хәленне белдерү, чагылдыру. *Гаязның зур булып ачылган кара күзләре тирән гажәпләнү билгесе күрсәтәләр иде.* М. Әмир. [*Зөләйха:*] *Егетлек күрсәтә алсаң, үзеңне көлкедән, безнең фамилияне хурлыктан коткару синең кулыңда.* М. Фәйзи. || Нинди дә булса мөнәсәбәтне белдерү, чагылдыру. [*Кәрим:*] *Дуслыкны шундый вакытта да күрсәтмәгәч, кайчан күрсәтер.* Г. Камал.

5. Гәүдәләндерү, чагылдыру; сәнгать әсәрендә сурәтләү. *Атказанган артист Х. Сәлимҗанов халыкның зирәклеген, тапкырлыгын, җитезлеген Байтирәк образында шактый тулы күрсәтте.* М. Җәлил. *Мәгъри белән Гайни әсәрдә бөтенләй кире типлар итеп күрсәтеләләр.* М. Гали.

6. Өйрәтү; ничек эш итәргә кирәклеген аңлату. *Безнекеләр аңлап алдылар һәм, канаудан чыгып, күрсәткән якка таба ашыкмыйча гына атлап киттеләр.* Ә. Еники. *Шулай, әткәй, Ленин юл күрсәтте Юлдан язар усал улыңа.* Һ. Такташ. || Исбатлау, дәлилләү. *Авыл тормышын никадәр сөйгәнемне эш белән күрсәтермен.* М. Фәйзи.— *Кемнең [хаклы] икәнен хәзер үк әйтү читен. Тикшерү күрсәтер.* К. Нәҗми.

7. Нәрсәне дә булса шартлы билгеләр, шартлы юл белән чагылдыру, билгеләү. *Хезмәт җитештерүчәнлегенең үсүен график юл белән күрсәтү.* || Төрле приборларның температура, басым, юнәлеш һ. б. ш.ны белдерүе турында. [*Компастагы*] *стрелканың кара төскә буялган очы һәрвакыт төньякны, буялмаган очы көньякны күрсәтә.* Физ. геогр.

8. Кайбер исемнәр янында килеп, шул исем мәгънәсенә бәйләнешле эш-хәрәкәт башкаруны белдерә. *Игелек күрсәтү. Саранлык күрсәтү. Юмартлык күрсәтү.* □ *Андреев [Мостафинның] кайбер хаталарына карата йомшаклык күрсәтүен икърар итә.* Ә. Еники. [*Ярулла:*] *Мине туган аталары кебек күреп каршы алдылар, күчү өчен бөтен ярдәмне күрсәтергә булдылар.* Ф. Бурнаш.

9. Кемнән дә булса карату, тикшертү: асылын ачыклату (күбрәк авырулар турында). [*Камали:*] *Хуш, тагы нәрсәләр дип әйтәләр дидең, докторга күрсәтербез, дип әйтәләр дисеңме?* Г. Камал.

10. Билгеле бер максат өчен (мәсәлән, сайлау өчен) исемен атап, тикшерергә, фикер алышырга тәкъдим итү. — *Беренче мәсьәлә — авыл советына председатель сайлау. Кандидатлар күрсәтүегезне сорыйм.* Һ. Такташ. *Волость советына сайланган илле депутатның утызы алар күрсәткән кешеләр иде.* И. Гази.

11. Нинди дә булса нәтиҗәгә ирешү (ярышта, конкурста, спортта һ. б. ш.). *Йөгерештә яхшы нәтиҗә күрсәтү.*

12. Допрос вакытында таныклык бирү. [*Рәхим:*] *Атаңны аттылар, абыеңны яптылар, докторны да, следовательне дә ялган күрсәтүләре өчен утырттылар.* Һ. Такташ.

13. *сөйл.* Шелтәләү, кирәген бирү; үч алу. [*Габсаттар:*] *Тукта әле, җебегән малай, мин сине өйрәтермен әле, сиңа гыйшык тотуның ничек икәнен күрсәтермен.* Г. Камал.

14. *ярд. ф. функ.* Нинди дә булса эш-хәрәкәтне кешеләргә аңлату йөзеннән башкару, үтәү; мисал өчен башкарып карау. *Газинур борын эченнән көйләп тә күрсәтте.* Г. Әпсәләмов. [*Фәрит:*] *Мин аңа шигырь сөйләп күрсәтермен.* Д. Аппакова.

Күрсәтү алмашлыклары — теге яки бу предметка күрсәтүне белдергән алмашлык (мәсәлән, **бу, теге, шул**). *Күрсәтү алмашлыклары, исемнән башка килсәләр, тартым һәм сан белән төрләнәләр.* Д. Тумашева.

КҮРШЕ *и.* **1.** Кем белән дә булса якында гына яки янәшәдә, каршыда яшәүче, торучы кеше. *Күршеләр, туган-тумачалар кереп, кайгырышып, елашып чыктылар.* Г. Бәширов. *Әтисе базарга чыгып киткән, әнисе, Габдуллага өйдә утырырга кушып, үзе каядыр күршеләргә йомыш белән чыккан иде.* Ә. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Янәшә яшәүче (торучы), якында яшәүче (торучы). *Шуннан соң ул күрше карт белән алар дус булып киттеләр.* Ш. Камал. *Күрше әбиләрнең әнигә булышлык итүләре аркасында, бу әйберләр дәррәү хәзерләнеп беттеләр.* М. Гафури.

2. Кем белән дә булса иң якында яки янәшәдә урнашкан кеше. *Мисбах автоматын муенына элде һәм, көч-хәл белән шуышып, күршесе янына килде.* Г. Әпсәләмов. *Ябылган кичтә үк ике як күршесе дә [төрмә стенасына] чиертә башладылар.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Янәшә булган, якын булган, янәшә урнашкан. *Очып йөргән мәгърур тау бөркете Килеп куна күрше кыяга.* Ф. Кәрим. *Күрше бакчада бөтен һаваны яңгыратып сандугач сайрый иде.* Ф. Әмирхан.

3. *с. мәгъ.* Бер-берсенә чиктәш булган административ, хуҗалык берәмлекләре турында. *Күрше дәүләт. Күрше колхоз.* □ *Күрше районга капчыклар алып киткән колхоз председателе Шәйхи абзый икенче көнне Яушырмәгә кайтып килә иде.* Ә. Еники.

Күрше булу, күрше булып тору — янәшә яшәү; бергә яшәү. [*Җамалый:*] *Без синең белән утыз ел күрше булып тордык.* Һ. Такташ.

◇ **Күршегә кереп торырга түгел, күршегә кереп торасы юк** — „үзебездә дә бар“ дигән мәгънәне белдерә. [*Камышев:*] *Тәҗрибәң ике кешегә җитәрлек! Осталык өчен дә күршегә кереп торасың юк.* И. Гази. **Күршегә керү** — берәр нәрсәне күршедән алып тору.

КҮРШЕДӘШ *и.* Кемгә дә булса күрше булып яшәгән кеше. *Иҗади дуслыктан тыш, бу ике талант бер-берсенә күршедәш тә булганнар.* Х. Сәлимҗанов.

КҮРШЕ-КОЛАН *җый. и. сөйл. к.* күрше-күлән. *Гөлсем апа озата керүче күрше-колан белән кул кысышып күрешеп чыкты.* Г. Гобәй. *Аларның мәхәббәтләренә күрше-колан арасында хәвефләнә төшебрәк караучылар да булмады түгел, булды.* Г. Минский. | *с. мәгъ. Рабига белән Зәйтүнә, күрше-колан хатынкызлар белән берлектә, ирләрне тау башындагы иске, ташландык җил тегермәненә чаклы озата бардылар.* К. Нәҗми.

КҮРШЕ-КҮКЕРТ *җый. и. сөйл. к.* күрше-тирә. *Председатель Сафин килеп җитте, авылдашлар, күрше-күкертләр җыелды.* Г. Сабитов.

КҮРШЕ-КҮЛӘМ *җый. и. сөйл. к.* күрше-күлән. [*Җәләл:*] *Әнкәй дә, сеңел дә, акыллырак кардәш-кабилә дә, күрше-күләм дә мәслихәт таптылар.* Ш. Камал.

КҮРШЕ-КҮЛӘН *җый. и. сөйл. к.* күрше-тирә. *Балачага артыннан кардәш-ырулар, күрше-күләннәр агылды.* Г. Ибраһимов. *Ул арада Газинурның кайтуын ишеткән күрше-күлән керә башлады.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Янәшә булган, янәшә урнашкан; якындагы. *Алар кичә иртә белән, атка атланып, тирә-яры мәсьәләсе буенча күрше-күлән авылларга чыгып киттеләр.* И. Гази.

КҮРШЕ-КҮРПЕ *җый. и. сөйл. к.* күрше-тирә. *Минем абыемны бөтен күрше-күрпе мактап сөйлидер иде.* Ф. Әмирхан.

КҮРШЕЛЕК *и.* Күрше булу, янәшә яшәү. [*Кафия:*] *Күршелек хакына Натолько бер чәчәк өзеп бирмәсме икән?* И. Гази. *Күршелек кардәшлектән якын.* Мәкаль.

КҮРШЕ-ТИРӘ *җый. и.* Күршедә яшәүче кешеләр, күршеләр. [*Әхтәм бабай*], *кыш булса, чабата тукый, --- күрше-тирәләргә* [*киез итек*] *төбе сала.* Г. Гали. *Килен, күрше-тирәдән табып, тимер мич алып кайттылар.* А. Шамов.

КҮРӘ *бәйл.* 1. Нәрсәгә дә булса ярашлы рәвештә, аңа туры килеп; карата. *Чиләгенә күрә капкачы.* Әйтем. *Эшенә күрә хакы.* Әйтем. *Яшенә күрә шуклыкның чигенә чыккан бу малай мәзәккә дә бик сәләтле иде.* Г. Гобәй.

2. Фигыльләрдән соң килеп, шул фигыль белдергән „эш-хәл аркасында“, „шуның сәбәпле“ дигән мәгънәне аңлата. [*Ат*], *кызу чабудан яңарак туктаганга күрә, башын бер югары, бер түбән чайкап, ара-тирә пошкырып куя.* Ш. Камал. *Ул, асылда йөрәк кешесе булганга күрә, хайваннарның кичерешләренә бервакытта да салкын канлы булып кала алмый иде.* Ә. Еники.

3. *сөйл. Сөйләү, әйтү* кебек сүзләр янында килеп, „кемнең дә булса сөйләвенә караганда“, „кемнең дә булса әйтүенә караганда“ дигән һ. б. ш. мәгънәләрне белдерә. [*Салихның*] *сөйләвенә күрә, бөтен эше офицер тотуда булган.* Ш. Усманов. *Ишетүебезгә күрә, җәмгыять башлап шушы эшләрне* [*башкарырга*] *бүгеннән тырышачактыр.* Ф. Әмирхан.

КҮРӘГӘ *и.* Төше алып киптерелгән өрек, төшсез өрек. *Күрәгә компоты.* □ *Кара җимеш, йөзем һәм күрәгәне җылы суда ике-өч кат югач, тәлинкәләргә салып куялар.* Хал. ашлары.

КҮРӘЗӘ *и. сөйл.* Күрәзәче. *Күрәзәнең сүзе йөрәгендә кара канлы агу белән катып торды, кая гына атласа да, кемгә генә барса да, ничек кенә күз яше түксә дә, якты чырай тапмас кебек булды.* Г. Ибраһимов. *Хан бу сәер кешегә игътибар итә. Күрәзәгә аның һәм үзенең сакалына ымлап күрсәтә.* Н. Исәнбәт.

КҮРӘЗӘЛЕК *и.* 1. Хорафат карашлар буенча: нинди дә булса магик алымнар белән киләчәкне күрү, билгеләү эше, шул юл белән нәрсәне дә булса белү эше. [*Әхмәт:*] *Көзгем әйтә: --- төнлә барса — уңар, ди, иртә барса — туңар, ди.* [*Шәйхулла:*] *Күрәзәлегең бик күңелгә ятышлы чыкты. Күпме хак бирим?* Д. Аппакова.

2. *сөйл.* Фараз итү, гөман итү; алдан күрү. [*Әни:*] *„Шулай бәхетсез булып яшәрсең“, — дип орыша торган иде үземне. --- Ләкин тормышымның ахыргы өлеше турында әнинең күрәзәлеге дөрес чыкмады.* М. Гали. *Бу турыда сүз кузгалгач, Өлгер Бикмулла үзенең күрәзәлеге белән мактанмыйча булдыра алмады.* Ә. Еники.

Күрәзәлек итү (кылу) — 1) күрәзәлек белән шөгыльләнү; 2) гөман итү, фараз итү. *Исхак институтан китмәде. Дөрес күрәзәлек итмәде юрист.* А. Гыйләҗев. *Хәер, нигә алдан күрәзәлек кылып торырга, анысын әле киләчәк күрсәтер.* Ф. Хөсни.

КҮРӘЗӘЧЕ *и.* Күрәзәлек (1 мәгъ.) белән шөгыльләнүче кеше, күрәзәлек итүче кеше. *Ул кылмаган им-том, ул бармаган күрәзәче, имчеләр калмаган.* З. Бәшири.

КҮРӘЗӘЧЕЛЕК *и. сөйл. к.* күрәзәлек (1 мәгъ.). *Күрәзәчелек һәм аңа ышану—искелектән калган, дин калдырган черек мирас.* Соц. Тат.

КҮРӘКАРАУ *и. к.* күрә карау („күрү“ сүзендә). [*Аяз:*] *Мин бит күрәкарау, миндә тавык күзе.* Г. Бәширов.

КҮРӘ-КҮРЕШКӘ *рәв. сөйл. к.* күрә-күрештән. *Күрә-күрешкә ошамау.*

КҮРӘ-КҮРЕШТӘН *рәв. сөйл.* Беренче мәртәбә очрашуда, беренче мәртәбә күрешүдә. *Минем белән тәкәллефле генә күрешсә дә, күрә-күрештән үк ул миңа ошамады.* Г. Рәхим.

КҮРӘЛМАУ *ф. сөйл.* Берәр кешегә яки берәр нәрсәгә карата нәфрәт хис итү. *Дәүләтшин хәзер үзе дә аңламый башлады инде: әллә ярата, әллә күрәлмый ул шушы Разияны.* И. Гази. [*Закиров:*] *Барлык хатын-кызларга да шулай шикләнеп карыйсың. Кайчакларда син аларны күрәлмау дәрәҗәсенә кадәр җитәсең.* А. Шамов.

КҮРӘЛМАУЧЫЛЫК *и.* Күрәлмау, күрәлмау хисе. [*Галим:*] *Беләсе иде: Англиянең, Франциянең, Германиянең яки Американың миңем кебек бер яшь кешесен нинди уйлар борчый икән? Әллә фашистлар аны да кеше күрәлмаучылык агуы белән агуларга өлгергәннәр микән?* Г. Әпсәләмов.

КҮРӘЛӘТӘ *рәв.* 1. Белә торып, күрә торып, белгән килеш, юри. — *Невод чуала дип,* [*Исак*] *кешеләрне күрәләтә батарга җибәрә.* Ш. Камал. — *Нигә безгә күрәләтә башны таш капчыкка тыгарга?* И. Гази.

2. Ачыктан-ачык, турыдан-туры; бер дә тартынмыйча, күзгә карап. [*Садыйк:*] *Күрәләтә ялганлый бит!.. Кем өйрәткән моны.* Г. Ибраһимов.— *Баланы күрәләтә шулай җәберләргә ирек бирмәм.* Г. Гобәй.

КҮРӘЛҮ *ф. сөйл.* Күрә алу; күрә белү (*күрә алу* тезмә фигыленнән кушылып килеп чыккан сүз). *Мең-гән саен җирнең матурлыгын, яктылыгын күбрәк күрәлдем.* Һ. Такташ.

КҮРӘМСЕҢ *кер. сүз. сөйл. к.* күрәсең. *Бу кеше, күрәмсең, үзенең әйтүенә караганда, эшчеләр конференциясенә тимер юл депосыннан делегат булып катнашкан.* Ш. Камал.

КҮРӘН *и.* Сазда үсә торган тар озын кыяклы күпьеллык үлән; *русчасы:* осока. *Агачлардан дымлы урынларда үсә торган зирекне, үләнчел үсемлекләрдән һәртөрле күрәннәрне, әт тиргәнген --- күрсәтергә мөмкин.* Ботаника. *Атыр чәчкә бу көндә бар үләннәр, Үсәр суда камыш белән күрәннәр.* М. Гафури.

КҮРӘНӘК *и. диал.* Нинди дә булса бер үрнәк яки гыйбрәтле сабак. *Күргәннән күрәнәк ал.* Мәкаль.

КҮРӘНЧӘЛӘР *и. бот.* Күрән, камыш һ. б. ш. үсемлекләр кергән бер өлешле күпьеллык үлән үсемлекләр семьясы.

КҮРӘСЕ *и. сөйл. к.* күрәчәк. [*Хәдичә түти:*] *Бар икән күрәселәрем. --- Бу кадәр рәнҗетүең өчен, бер үк, телең корсын!* Г. Бәширов.

КҮРӘСЕҢ *кер. сүз.* Ахрысы, булса кирәк, бугай. *Чиккән башлы сөлгене Фәйзигә авылдан җибәргәннәрдер, күрәсең.* Ш. Камал. *Күрәсең, аңа бик ачык булган нәрсәләр дә кайберәүләр өчен куе томан икән әле.* Г. Бәширов.

КҮРӘЧӘК *и. сөйл.* Кичерергә, күрергә тиеш булган нәрсә; тәкъдир, язмыш. [*Ярулла:*] *Бүген күрәчәкне күз алдыма китерсәм, ач үлсәм дә, атымны бу эшкә бәйләмәгән булыр идем.* Ф. Бурнаш. *Авыр еллар, Сезнең кулыгызда Күрәчәкне бик күп күрдек без.* Һ. Такташ.

КҮРҮ *ф.* 1. Күз белән кабул итү, карап сизү. *Айлар буе юеш окопларда ятучы сугышчылар, Таняны күргәч, ничектер үзгәреп китәләр иде.* А. Әхмәт. *Укымышлы малайны күреп кенә чыгар өчен күрше-күлән, кыз-кыркын әллә никадәр сылтау таптылар.* Ә. Фәйзи. || Очрату. *Күргән саен чакыра, барып карарга бары Шәрифулла гына вакыт таба алмый.* А. Шамов. [*Садыйк:*] *Алай булгач, менә нәрсә, балам: монда үзебезнең кешеләрдән кайберәүләрне күреп, миңа сөйләшергә кирәк.* Ш. Камал.

2. Күз белән карап сизү сәләтенә ия булу, күрә алу. *Күз күрмәгәч, ау ауларга хәле килми, Ачыгып беркөнне бу хәлдән тайды.* М. Гафури. [*Бабай:*] *Карчык кешене беләсез бит, күзләре күрми башлаган: аиртә белән кәҗә бәрәннәре белән бергә песине дә көтүгә куган.* Г. Гали.

3. Аңлау, төшенү; сизү, белү. [*Яңгура:*] *Мин дә сезне күреп җиткерә алмаганмын. Сез күзгә төтен җибәрергә нык остарып кайткансыз.* Г. Әпсәләмов. *Бу надан студенттан эш чыкмаганын күргәч, мин икенче ягымдагы утыргычка таба әйләндем.* Ф. Әмирхан. || Кемдә яки нәрсәдә дә булса берәр хәлне, үзенчәлекне билгеләү, берәр төрле үзенчәлек табу, сизү. [*Укытучы:*] *Мин сиңдә булачак шагыйрьне күрәм, Сәлим.* Г. Гобәй. *Әгәр без Горькийның --- хәтта дөнья күләмендә әсәрләре басылып тарала башлаган заманнардан алып карасак, аңа җәмгыятьтә үзенә юл йөртү алай җиңелгә килмәгәнен күрербез.* Г. Нигъмәти.

4. *күч.* Кичерү, баштан үткәрү; берәр нәрсәгә дучар булу. *Боларның кайберләреннән Нәгыйм беркадәр җәбер дә күрде.* Ш. Камал. *Ул әллә никадәре битәрләүләр, начар сүзләр, кара тормышлар күрде.* М. Гафури. || Берәр нәрсәнең яки берәр эшнең нәтиҗәсен үз тормышында тату, тою, сизү. [*Абыстай*] *бар малының һиммәтен күрәдер, тора беләдер.* Ш. Мөхәммәдев. [*Нуретдин:*] *Чынлап тотынганда, иң якын елларда фермабызның игелеген күрә башларбыз.* Ә. Еники. || Нинди дә булса күңелсезлеккә, авырлыкка очрау, берәр авырлык кичерү. *Әмма 1905 елны 74 миллион зарар күргәннәр.* Урал.

5. Нинди дә булса бер максатка ирешү; берәр хәлгә ирешеп, шул хәлдә яшәү, тору. *Без дә күрдек бу көннәрне, тормышлар бөтенләндә.* М. Фәйзи. *Тик колхозда гына без дә күрдек Адәм санына кергән көннәрне!* Ш. Маннур. || Берәр нәрсәгә ия булып, аңардан файдалану, аның белән эш итү.— *Безнең аның шикелле акча гына күргәнебез бар.* Г. Камал.— *Ата-баба күрмәгән асыл күлмәкне киеп карыйк әле.* А. Әхмәт.

6. Кем яки нәрсә дип санау, исәпләү, уйлау; кем яки нәрсә дип табу. *Акчаның беткәнен сизгәч, Хәсәншаның иң якын күргән дуслары да берәм-берәм ычкына башладылар.* Ш. Мөхәммәдев. *Сабир абзый, Сәйфуллаһы улы кебек күргәнгә, беренче чәйдән үк аракы белән сыйлауны килештермәде.* Ә. Еники. || Берәр нәрсәнең сәбәпчесе итеп тану, берәр эштә гаепле дип санау. *Атасы --- Зәйнәпне битәрли, эще уңмаганлыкларны Зәйнәптән күрә.* М. Гафури. [*Йосыф:*] *Әгәр дә мәгәр --- минем Габдулла дус белән берәр хәл булганын ишетсәм, синнән генә күрермен.* Ә. Фәйзи.

7. Кайбер исемнәрдән соң килеп, шул исем белән белдерелгән эш-хәлне башкаруны, үтәүне аңлата. [*Хөрмәтулла:*] *Аннан инде яңадан фронтка барырга исәбем юк, өяздәге түрәләрнең көен күргә кирәк, анда да акча диярләр.* Т. Гыйззәт. [*Якуп:*] *Кичә мин больницада булдым: яралыларны кабул итү өчен ашыгыч хәзерлек күргә куштым.* И. Гази.

8. *а, ә, и, й* гә беткән хәл фигыльләрдән соң килеп, боерык фигыль формасында үтенүне, ялынуны яки боеруны яисә теләкне белдерә. [*Нәгыймә:*] *Ярар, кызым, бар. Минем өчен эшеңнән кала күрмә.* Г. Камал. [*Разия:*] *Сезнең белән юньләп исәнләшә дә алмадым, кичерә күрегез.* Г. Ибраһимов.

9. *рәв. мәгъ.* **күреп.** Кемгә дә булса ияреп, үрнәк алып. *Бездән күреп күрше колхозлар да шулай эшли башладылар.* Ә. Айдар. *Аны, әлбәттә, һичкем мәҗбүр итмәде, ул абыйсы белән апасыннан күреп эшләде.* Г. Гобәй.

10. *кер. сүз функ. сөйл.* **күр.** Гаҗәпләнүне белдерә: кара инде. [*Гарәфи:*] *Күр, без вагонга утырганнан бирле яткан урыныбыздан кузгалганыбыз юк.* Г. Әпсәләмов.

11. *кер. сүз функ.* **күрерсең, күрерсез, күрербез.** Киләчәктә ачыкланыр, киләчәктә билгеле булыр. [*Маликә:*] *Күрербез, кем кемне әйләндереп салыр, чебешләрне көзли саныйлар аны!* И. Гази.— *Ачулары гына чыгып җитсен, менә күрерсең, Аланбашларыңны түгел, әллә кемнәрне узып китәрбез!* Г. Бәширов.

12. *ярд. ф. функ.* 1) әчтәлеге „итү“ ярдәмче фигыленең мәгънәсенә туры килеп, исемнәрдән тезмә фигыль ясый. *Ашлыкны кыш көне әвен белән сугуда әллә ничаклы файда күрә.* Г. Ибраһимов. *Өстәлдәге дәфтәрнең пароход машинасы белән ничек-ничек эш күрәсен өйрәткән җирен укып чыкты.* Ф. Әмирхан; 2) *сөйл.* әчтәлеге белән „карау“ дигән ярдәмче фигыльнең мәгънәсенә туры килеп, *ып-еп* формалы хәл фигыльгә кушылып тезмә фигыль ясый. *Гомерендә бер мәртәбә булсын либретто язып күрмәгән яки опера тәрҗемә итмәгән кешегә --- зур либретто язарга яки зур операны тоташ тәрҗемә итәргә тапшыру мөмкин түгел иде.* М. Җәлил. — *Татып күрсен инде хәзер Ачы үлем чишмәсен.* Ф. Бурнаш.

Күрә алмау — *к.* күрәлмау.— *Булатның әнкәсе мине күрә алмый, мине үзенә дошман саный.* Г. Ибраһимов. *Бу типларны шул кадәр көлкеле кыяфәттә бирү өчен, шул тормышны бик ныклы белү өстенә, күрә алмаслык дәрәҗәдә аңа ныклы дошманлык хисе булуы кирәк.* М. Гали. **Күрә карау** — ерактан начар күрү, ерактан ачык күрмәү. *Балалар еш кына караңгылыктылы вакытта, кайчакта трамвайда --- барганда укыйлар. Болар бар да күзгә артык көч китерә һәм ерактан күрә алмауны (күрә карауны) китереп чыгара.* Анатомия. *Кыз бераз гына күрә карау булса да, „йөзне боза“ дип, күзлек кими иде.* А. Гыйләҗев. **Күрә караучы** — ерактан начар күрүче. *Өстенә свитер кигән чандыр гына бер кеше, өстәлгә бик ныклы елеп, күрә караучы кешеләргә генә хас бер кыяфәт белән нәрсәдер язып утыра.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Күр дә тор** *кер. сүз. сөйл.* — һичшиксез, чыннан да, чынлап та. [*Айдар:*] *Сүзеңне үлчәп сөйләмәсәң, күр дә тор, телеңне суырып алып, колак тишегеңә тыгып куярмын.* Ф. Хөсни. **Күрер күзгә** — беренче карашка; карап торганда, караганда. *Күрер күзгә матур чәчәк, күтәрергә авыр чәчәк.* Табышмак. *Күрер күзгә чибәр түгел, әллә нигә яратам.* Җыр. **Күрми калу** — игътибарсызлык аркасында нәрсәне дә булса югалту, кулдан ычкындыру. [*Ю. Дамскийга*] *каршы уйнаган В. Конюхов уенны отарлык итеп дәвам итә алмады һәм шуның өстенә ладьясын „күрми калды“.* Соц. Тат. **Күрмәгәнне (күрмәгәнен) күрсәтү** — бик ныклы әрләү, шелтәләү, тиргәү яисә кыйнау; кирәген бирү, өйрәтү. [*Габит:*] *Туктa, мин моңа күрмәгәнен күрсәтим әле,—дип, өйгә керде дә мич башыннан кипкән чыра агачы белән бер бау кисәге алып чыкты.* Ф. Кәрим. **Күрмәгәнне күрү** — бик авыр хәлгә очрау, бик авыр хәлгә калу; нинди дә булса җәза алу.— *Ярый, бәхете бар икән, китеп котылды, күрмәгәнен күргән булыр иде.* А. Алиш. **Күрә торып** — ачыктан-ачык, бер дә тартынмыйча, оятсыз рәвештә. [*Вәли карт:*] *Күрә торып, кеше җиренә, кеше хакына керәсез!* Ш. Камал.

КҮСЕ *и.* **1.** Тычкансыманнар семьялыгыннан тычканнан зур, соры йонлы, озын койрыклы кимерүче хайван. *Күзне генә йомасың, кровать каршындагы комод тартмасында күсе кытырдый.* Г. Тукай. *Песи күргәч, күселәр Койрыкларын кыстылар.* М. Җәлил.

2. *күч. сөйл.* Нинди дә булса тыныч һәм табышлы урында эшләп, рәхәт яшәүче кешегә карата нәфрәт хисе белән әйтелә. *Чиркәү күсесе.* □ *Хатны Гөлнарым миңа үпкәләп язган, янәсе --- мин тыл күсесе булып рәхәттә ятам.* Ә. Айдар.

КҮСТЕНҮ *ф. диал.* Үксү, үксеп кую. *Зәгыйфь вә кызганыч бер мәхлук, --- йомшак кына җан сулыш белән күстенеп-күстенеп, бертөрле йокы белән --- йоклый иде.* Ш. Камал.

КҮСТӘРҮ *ф. иск. к.* күрсәтү. *Йөзең күстәр, [пәрдәңне] ач.* Г. Тукай. *Хөрмәтле укучыларымызга хикәяләнең бәһадирлары күстәрелде.* З. Һади.

КҮСӘ *с.* 1. Сакалсыз, сакалы булмаган яки сакал төкләре бик сирәк булган. *Күсә кеше.* □ *[Мәрфуга:] Ул арада Фәтхие килеп чыккан булган. Күсә сакалын сыпыргалаган булып: „Нигә безгә килеп йөриләр?“ — ди.* М. Фәйзи.

2. *и. мәгъ.* Сакалсыз, сакал үсмәгән кеше. *Һәр сакаллы берәр төк бирсә, күсә дә сакаллы булыр.* Мәкаль.

КҮСӘК *и.* 1. Бәрү, ору, сугу, авыр әйберләрне каерып күтәрү һ. б. ш. өчен кулланыла торган, бер башы юанрак, икенче башы тотар өчен юнып нечкәртелгән агач кисәге. *[Крестьяннар] таяклар, күсәкләр белән [егетне] сугарга, аяк белән башын, күкрәген изәргә омтылдылар.* Г. Ибраһимов. *Кызларыбыз, теге күсәк белән яраланган иптәшләребез тирәсенә җыелып, җәрәхәтләрен яза, сылый вә бәйли башладылар.* Ф. Әмирхан.

2. *күч. гади с.* Аңгыра яки тупас кеше турында. *Теге күсәк, үзе генә калгач, бигрәк иркенләде.* Ак юл. *Тик китә кайчакта кәйфең, хакимең булса ишәк, --- мәхәббәтсез, күсәк һәм килмешәк!* Г. Тукай. | *с. мәгъ. [Шәмгун:] Әллә чынлап та теге күсәк малай безнең кызлар янына чумганмы?* Т. Гыйззәт. || Нинди дә булса тупас көч турында. *Патша заманының тупас күсәге — кызыл борынлы исерек урядниклар аларның яшьлек истәлегендә имәнеч шомлы карачкы булып гәүдәләнеп калган.* Г. Бәширов.

Күсәк күтәрү — каршы чыгу; каршы булу; көрәшү. *— Татарның буржуазиясенә каршы күсәк күтәрү мәсьәләсенә килгәндә, бер көнге мәҗлестә мин сезгә ул турыда кыска гына җавап биргән идем.* Ш. Камал.

КҮСӘКЛӘШҮ *ф. сөйл.* Күсәкләр белән сугышу, күсәкләр белән кыйнашу.

КҮТӘМӘ *и. зоол.* Вак балыкларның бер төре, зурлыгы ягыннан эт балыгы һәм ташбаш балыгыннан беркадәр кечерәк; диалектларда, „меле“, „мылы“ яисә „транҗа“ дип йөртелә; *русчасы:* малёк.

КҮТӘРГЕЧ *и. махс. к.* күтәрткеч. *Гидравлик күтәргеч. Күтәргеч машинисты.*

КҮТӘРЕЛЕШ *и.* 1. Үзенең экономик, сыйнфый, милли һ. б. интересларын яклап, изелгән сыйныфларның хакимлек итүче сыйныфларга каршы чыгыш ясавы; иске иҗтимагый стройны юкка чыгару һәм яңа строй төзү өчен кораллы восстание. *Бишенче елның декабрь күтәрелеше бастырылып, Россия буйлап җәза отрядлары чаба башлаган заман иде.* Г. Нигъмәти. *[Мирвәли:] Изелгән сыйныфларның күтәрелешенә каршы эксплуататорлар сыйныфы ерткычларча чәйнәшә.* Т. Гыйззәт. || Дәүләт властена каршы заговор юлы белән оештырылган кораллы чыгыш; бунт, фетнә. *Ләкин бу — күзен кан баскан, котырган кулак күтәрелешен җиңәргә ялгыз егетнең көче җитә алмады.* Г. Ибраһимов.

2. Нәрсәнең дә булса көчле үсүе, зур үсеш алуы турында. *Соңгы берничә елда кинода һәм театрда Ленин образын чагылдыра башлау совет сәнгатенең күтәрелешен билгели торган бер факт булып тора.* М. Җәлил. *Промышленность торгынлыгы --- промышленность күтәрелеше белән алышынды.* КПСС тарихы.

КҮТӘРЕЛМӘ *с.* 1. Күтәрелә торган, күтәрелеп ачыла торган. *Күтәрелмә күпер.*

2. *лингв.* Тоны күтәрелә торган. *Күтәрелмә дифтонг. Күтәрелмә интонация. Күтәрелмә басым.*

Күтәрелмә сабак *бот.* — турыга үскән сабак; *к.* туры сабак.

КҮТӘРЕЛМӘЛЕ *с. к.* күтәрелмә. *Бу чокырдан үтү өчен күтәрелмәле күперне төшерергә кирәк булачак.* Ә. Айдар.

КҮТӘРЕЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* күтәрү.

2. Югарыга менү. *Алар искереп, җимерелеп барган агач баскычтан тиз-тиз генә күтәрелделәр.* А. Шамов. *[Җәмилә], мунчалары турына җиткәч, --- ярдан күтәрелдә.* Г. Гобәй. || Түбәннән югарыга таба сузылу, түбәннән югарыга бару (юл һ. б. турында). *Китүчеләр бер төркем булып, приискалардан кырга таба күтәрелгән юл белән әкренләп кенә алга киттеләр.* М. Гафури. *Каюм белән Әхмәт, насостан шанга күтәрелгән трубаның башын насос тулысынча эшләгән вакытта тикшергәч, икенче фикергә килделәр.* Ш. Камал. || Биек булып югарыга ашу; югарыга таба сузылу. *Бөгелмәнең биек-биек йортлары, завод трубалары, мәһабәт кыя сыман күтәрелгән элеваторы да күптән инде күздән югалуга карамастан, Газинур һаман да тәрәзә яныннан китмәде.* Г. Әпсәләмов. *Куркыныч яр булып күтәрелгән биек тау да бу җирдә сөзәкләнеп озайган иде.* М. Әмир.

3. Югарырак хәлгә, торышка килү; югарыга таба күчү. *Картның сохари тоткан куллары өскә күтәрелделәр.* А. Әхмәт. *Илсөяр таныган кешенең күзләре әз генә зураеп киткән төсле булды, кашы зураеп өскә күтәрелде.* Г. Гобәй. || Беркадәр югары торышка килү; биегәю өчен аяк очларына басу. *[Рәшит] бармак очларына гына басып күтәрелде дә кассага акча сузды.* А. Әхмәт. || Вертикаль юнәлештә хәрәкәт итеп ачылу. *Газинурның җыры ишетелгәч, Гали абзыйларның кечкенә өендә ак тәрәзәнең ак пәрдәсе күтәрелде.* Г. Әпсәләмов. *Пәрдә күтәрелгәндә, кара-каршы җырлашу бара.* М. Фәйзи.

4. Утырган яки яткан урыннан тору, басу. *Дәүләтшинның автоматчылары, дәррәү күтәрелеп, корым, төтен, тузан белән капланган алма бакчаларына кереп югалалар.* И. Гази. *Провокаторга хәтле үк җирдән күтәрелгән командир гимнастеркасын рәтләде.* Г. Гобәй. || Һавага очып менү. *Тирә-юньне яктыртып, һавага өзлексез рәвештә ракеталар күтәрелә.* А. Шамов. || Югарыга ургылып чәчелү, өскә тузылу (тузан, кар). *Урамда күз ачып булмаслык тузан күтәрелгән.* Ф. Әмирхан.

5. Нинди дә булса биеклеккә җитү. *Су инде Илсөярнең балтырына кадәр күтәрелде.* Г. Гобәй. || Үсү, үсеп озынаю, биегәю (үсемлекләр турында). *Саматов җитлегеп килгән бодай басуларыннан, буйга күтәрелгән яшел кукурузалардан, мең төрле чәчәкләр белән бизәлгән болыннардан күзен ала алмыйча карап тора.* Г. Минский. *Яшелчәләр әле яңа гына күтәрелеп киләләр.* Ш. Камал.

6. *күч.* Кемнең дә булса фикерендә, карашында абруйлырак булып күренү, үскән булып күренү. *Вакыт үткән саен, комиссар улы аның каршында гел күтәрелә барды.* Г. Бәширов. — *Хатыным исә минем алда бары тик күтәрелде, үсте генә.* М. Хәсәнов. || Үсешнең югарырак дәрәҗәсенә ирешү, камилләшү. *Беренче татар опера театрының төзелүе — татар совет культурасының һәм. аерып алганда, татар совет музыкасының яңа баскычка күтәрелүен күрсәткән факт.* М. Җәлил.

7. Горизонт өстенә чыгу; өскә менү (кояш турында). *Урал аръягыннан күтәрелгән иртәнге кояш нуры бүлмәгә бәреп керде.* Ш. Усманов. *Кояш бераз күтәрелгәннән соң, шул авыллар өстендә берничә немец аэропланы күренде.* М. Гали. || Югарыга сузылу, юга-

рыга тартылу; югарыга китү. *Төтен күтәрелү.* □ *Күл читләре күк урман, Күтәрелә күк томан.* Ш. Маннур. *Каралтылардан, утын әрдәнәләреннән кызгылт-көрән төстә ялкын көлтәләре күтәрелә.* К. Нәҗми.

8. *кит.* Төзелү, салыну, барлыкка килү. *Аларга караганда да зуррак --- булып күтәрелгән ике яңа йорт кызыксындырды мине.* М. Әмир. *Күтәрелде яңа заводларың, Күтәрелде яңа йортларың.* Ә. Ерикәй. || Юлга салыну, яхшыру (таркалган хуҗалык турында).

9. *күч.* Үсү, үсеп чыгу, җитешү. *Күтәрелде оста инженерлар, Зур талантлы бик күп галимнәр.* Ә. Исхак. [*Сәгыйдә:*] *Соң бит, абый, бишъеллыкны үтәү өчен шахтадан күтәрелгән белгечләр кирәк.* Һ. Такташ. || Югары урын алу; югарырак иҗтимагый дәрәҗәгә ирешү. *Сугыш елларында гына спекуляция белән күтәрелгән яңа байларны Бикмөхәммәтев теләнче байлар дип йөртә иде.* Ш. Камал. *Синме, Зифа, синме шушылай хәзер Күтәрелдең эштә биеккә.* Ш. Маннур.

10. Нинди дә булса эш-хәрәкәткә бердәм рәвештә тотыну, оешкан төстә кузгалу. *Аның күз алдына бөек Москва һәм сугышка күтәрелгән бөтен туган иле килеп баса.* Г. Бәширов. [*Миронов:*] *Атакага күтәрелергә кирәк икән, беренче булып коммунистлар күтәрелде.* Р. Ишморат. || Баш күтәрү, восстание күтәрү. *Кузгал, күтәрел, эшче дөньясы, Дошманга каршы чык, ач халык!* К. Нәҗми. — *Патшага, алпавытларга каршы күтәрелгән кешеләрне* [*Бөгелмәгә*] *сөргенгә җибәргәннәр.* Г. Әпсәләмов.

11. Кайбер исемнәрдән соң килеп, эш-хәрәкәтнең башлануын, барлыкка килүен белдерә. *Бүлмәдә көлү, шау-шу күтәрелә.* Ф. Әмирхан. [*Биктимер:*] *Ай-яй, тышта буран күтәрелде, малларны ябып керим әле.* Т. Гыйззәт. || Нинди дә булса эш, мәсьәлә куелу. *Моңарчы күтәрелеп тә томалана барган мәсьәләләр яңарып калкып чыктылар.* М. Әмир. *Тавыш бер кузгалгач, „Хезмәт“не яңадан тикшерү эше күтәрелде.* Г. Ибраһимов. || Таралу, яңгырау; ишетелү. *Йоклаган халыкның хырылдау тавышы һавага күтәрелә.* Ш. Усманов.

12. Арту, зураю. *„Дәрәҗә“ күтәрелгәннән-күтәрелде, --- малайлар минем якын дус булып тору юлларын эзли башладылар.* М. Гафури. *Кыш көне мәдрәсәдә дә инде минем авторитет шактый күтәрелгән иде.* Ш. Камал. || Нәрсәнең дә булса микъдары, күләме арту турында. *Уңыш күтәрелү.* || Нәрсәнең дә булса бәясе арту турында. *Хезмәт хакы күтәрелү.* □ *Япониядә бәяләрнең күтәрелүе даими күренешкә әверелгән.* Соц. Тат. || Көчәю, интенсивлыгы арту. *Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы күченүләр белән зур зилзиләләргә җитә... тына... тагын күтәрелә.* Г. Кутуй. *Студия еллары яшь татар композиторларының иҗат активлыгы күтәрелү белән характерлы.* М. Җәлил.

◇ **Күтәрелеп бәрелү** — бик нык ачулану; ачуланган вакытта бик нык кызып китү; тузыну. *Гыйззәт ачуыннан күтәрелеп бәрелде.* Ш. Усманов. **Күтәрелеп карау** — башны күтәреп карау. *Бу сүзләрне ул шундый итеп әйтте, Мансуров ихтыярсыз аңа күтәрелеп карады.* Г. Бәширов. **Күтәрелмәгән чирәм** — берәр фән өлкәсендә эшкәртелмәгән яки бик аз өйрәнелгән мәсьәлә, проблема.

КҮТӘРЕҢҮ *ф.* Үз әйберләрен күтәрү, әйберләрен үз өстенә салу яки кулга тоту. *Яр кырыенда пароход көтүчеләр күтәренеп дебаркадерга йөгерделәр.* М. Гали.

КҮТӘРЕНКЕ *с.* 1. Тирә-якка караганда бераз биегрәк, бераз күтәрелә төшкән; калку. *Инешнең аръягында --- биек булмаган күтәренке таучыкларны каплаган әрәмәлек — бәләкәй урманлык башлана.* Ш. Камал.

2. Югары, зур.— *Дәе,* [*авыруның*] *температурасы күтәренке булырга кирәк.* А. Шамов.

3. Шат, яңгыравыклы (тавыш турында). *Газета сатучы малайлар, --- нинди дер шатлык хәбәр иткән кебек, күтәренке тавыш белән кычкырдылар.* Ә. Фәйзи. *Иркен бакчаның кичке тынлыгын күтәренке көлү тавышлары яңгырата иде.* М. Әмир. || Шат, көр; дәртле (күңел, рух һ. б. ш.). [*Мансуров*] *Һәрвакыт күтәренке күңелле, бертөрле авырлыкка да бирелми торган нык кеше, көчле кеше булып күренсә дә, сугыш вакытында район белән җитәкчелек итүнең кыенлыгын үзе генә белә иде.* Г. Бәширов. *Бу шигырьләре аның күтәренке рух, чиксез шатлык һәм дәрт хисләре белән сугарылган.* М. Җәлил.

4. Югары, күтәрелгән, арткан (бәяләр турында). *Игеннәрнең бәясе шактый күтәренке тора иде.* А. Шамов.

КҮТӘРЕНКЕЛЕК *и.* Күтәренке булу, көр булу, шатлыклы булу (күңел, рух һ. б.). *Рух күтәренкелеге.* □ [*Гайшә*] *шунда ничаклы эшләсә дә, көч җыеп, күңел күтәренкелеге белән кайта иде.* Г. Ибраһимов. || Күтәренке күңел, күтәренке рух. *М. Гафури 1917 елгы Февраль революциясен зур күтәренкелек һәм өмет белән каршылады.* М. Җәлил. *Ул шатлык, күтәренкелекнең бер дә чиге-кырые да юк иде.* Ш. Камал.

КҮТӘРТКЕЧ *и. махс.* Йөкләрне яки кешеләрне күтәреп күчерү өчен җайланма, күтәрү машинасы; кран. *Төзелеш күтәрткече.* □ *Зур чуен челтәр күтәрткечләр Йөзә* [*Днепростройда*] *күккә табан.* Н. Исәнбәт. || Нинди дә булса авыр предметны яки авырлыкны беркадәр генә югарыга күтәртү өчен җайланма, домкрат. [*Автомобильнең*] *көпшәк шины ләшперәп төшкән, тәмам бушаган. Җирдә насос, күтәрткеч һәм ачкычлар таралып ята.* А. Шамов.

КҮТӘРМӘ I *и. диал.* Өйалды баскычы; болдыр. *Озак көттерми, контора ишеге ачылып, таза гәүдәле, --- аягына озын кунычлы итек кигән бер кеше чыгып, күтәрмәгә басты.* М. Гафури. *Мәрьям, --- зур ачкычын тотып, күтәрмәгә менде.* Н. Фәттах. || Баскычның менгәндә яки төшкәндә баса торган горизонталь басмаларының берсе. *Чиста итеп юган баскыч күтәрмәсенә, озын себеркесен тоткан килеш, Айтуган карт та килеп утырды.* Г. Бәширов.

КҮТӘРМӘ II *и. сөйл. к.* күтәртмә. *Гыйльми --- күтәрмәләрен ясап бетерә, каты юкә белән чабаталарына беркетә дә, без урамга чыгабыз.* Ш. Маннур. *Пычракта батмас өчен әтисе күтәрмә дә ясап биргән.* Соц. Тат.

КҮТӘРМӘЛЕ *с. к.* күтәртмәле. *Яр буенда күтәрмәле чабата кигән бәләкәй Хәллә йөгереп йөри.* Г. Сабитов.

КҮТӘРТМӘ *и.* 1. Яз яки көз көннәрендә, аякны юешләтмәс өчен, чабата яки юкә башмак астына куела торган ике агач шакмактан гыйбарәт җайланма. [*Егет*], *март башыннан ук күтәртмә тагып чыккан малай шикелле, башмагы белән бозлавык сукмактан атлап килә.* Ш. Маннур.

2. *с. мәгъ. к.* күтәрелмә (1 мәгъ.).

КҮТӘРТМӘЛЕ *с.* Күтәртмә куелган, астына күтәртмә беркетелгән (чабата яки юкә башмак турында). [*Гафият*] *аякларына күтәртмәле чабата, өстенә култык аслары сүтелгән, мамыклары чыккан солдат сырмасы кигән.* И. Гази.

КҮТӘРТҮ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* күтәрү.

2. Нинди дә булса корылманы югарыга күтәреп салу, биегәйтү, берәр нәрсә өстенә салу. *Ташу вакытында су кермәсен өчен баганаларга күтәртеп эшләнгән алачыкта бер карт тора.* Г. Гобәй.

3. *сөйл.* Нинди дә булса корылманы (мәсәлән, күперне) җимерү, шартлату, вату. [*Командующий:*] *Әгәр шул вакытка казаклар китмичә һаман ут алып барсалар, күперне күтәртеп, эшелоннарыгызга утырырсыз.* Ш. Усманов.

КҮТӘРӘМ I *и.* Печән җыйганда бер күтәреп алырлык итеп әзерләнгән печән өеме; күбә. *Галимә апа печәнне үзе биеклеге булганчы тәгәрәткәч, әтинең: „Галимә кызым, бик ерак китмә, --- анда җиткерә алмаслар, күтәрәмнәр тигез булсыннар, югыйсә чүмәлә салырга җайсыз булыр",— дип әйткәнен ишеткәч кенә туктады.* М. Гафури.

КҮТӘРӘМ II *и. сөйл.* Кеше күтәреп торгызырга я йөртергә калган хәлсез кеше яки арык терлек. *Аксак — күтәрәмнән яхшырак.* Мәкаль.

◇ **Күтәрәмгә калу (чыгу)** — азык җитмәү аркасында хәлсезләнеп, басып тора алмаслык хәлгә килү (терлек турында). [*Йөзлебикә:*] *Син туры әйт, ничә атың күтәрәмгә калган да ничәсе корчаңгы?* Г. Бәширов.

КҮТӘРҮ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса югарыга таба торгызу, вертикаль хәлгә китерү; өскә таба карату. [*Шофер*], *кабинасыннан чыгып, кулларын күтәрде.* Г. Гобәй. *Сукачылар ялт башларын күтәрделәр.* И. Гази. || Нәрсәне дә булса югарырак итү, биегрәк, калкурак итү. *Түтәл күтәрү.* □ *Аннары без, көрәкләребезне алып, беребезгә бер сүз эндәшмичә, һәркайсыбыз бердәй уйга батып, кабер туфрагын тигезләп күтәрдек.* А. Шамов. || Әйләндереп югарыга таба кайтару. [*Миңсылу*], *икенче ягында утырган Нәфисәнең итәген күтәреп, тиз генә үзенең битен, чәчен каплый башлады.* Ф. Әмирхан.

2. Кемне яки нәрсәне дә булса, куелган яки торган урыныннан билгеле бер көч белән аерып алып, җиргә (идәнгә) төшермичә тоту, тотып тору. *Разведчиклар, яшен тизлеге белән „тел"не күтәреп алып, куе караңгылык эченә кереп югалдылар.* А. Әхмәт. [*Сәмигулла абзый*] *бәйләп куелган төеннәрне һәм саквояжны күтәреп карады.* Ф. Әмирхан. || Кулда тоту, тотып алу. *Киемнәрне кулына күтәрә дә ярты Иделне чалкан йөзә дә чыга.* И. Гази. || Иелеп алу, иелеп җыеп алу (җирдән, идәннән). *Идәннән тәмәке төпчеген күтәрү.*

3. Югарыга, өскә таба күчерү, югарырак торышка китерү. *Зуррагы үткен нәрсә икән, түргә, тегү машинасы өстенә куелган лампаның филтәсен күтәрде.* Г. Ибраһимов. *Палатага няня кереп, тәрәзә пәрдәләрен күтәрде.* Ә. Айдар. *Карп Васильевич, --- күн кепкасын бармагы белән күтәреп, башын кашып куйды.* Г. Әпсәләмов.

4. Куптару, туздыру (тузан, кар һ. б. ш.). *Җил шыря лангач кыр буенча чаба, юлында очраган шәрә куаклар арасында сызгыра, корыган үләннәрне һавага күтәрә.* Г. Әпсәләмов. *Кызыл кавалериянең күтәргән тузаннары гына күренә иде.* Ш. Усманов.

5. *сөйл.* Нинди дә булса бурадан берәр корылма салу, төзү; әзер бураны мүкләп өю. *Мунча күтәрү.* □ *„Өй күтәрәм, өмәгә!" — дигән чакыру ишетелү белән, дхмәдиләр, Шәяхмәтләр, Шәнгәрәйләр, Ситдыйклар, Җиһанша бабайлар җыелып килделәр дә --- өйне аякка бастырдылар.* Г. Ибраһимов.

6. Кузгату, кую (мәсьәләне). *Бакчаны торгызу мәсьәләсен дә бит комсомол оешмасы күтәреп чыккан иде.* Г. Бәширов.

7. Күбәйтү, арттыру. — [*Галин*] *бөтен буяу цехында дисциплинаны ныгытты, эшләп чыгаруны моңарчы булмаган дәрәҗәгә күтәрде.* Ш. Камал. *Иген уңышын күтәрәбез, Эшлибез бер теләктән.* М. Җәлил. || Көчәйтү, чагылыш дәрәҗәсен арттыру. [*Басыйров:*] *Инженерлар һәм цех начальникларының җаваплылыкларын күтәрү турында кайбер фикерләрем дә бар.* Р. Ишморат. [*Искәндәрев*], *тавышын күтәрә төшеп, әйтә.* Ә. Еники. || Арттыру (бәяләрне). [*Капиталистик илләрдә*] *әйбер хакын күтәрергә Малны суга түгәләр.* Н. Исәнбәт. || Үстерү, арттыру. *Шулай, дуслар, күбрәк бирегез Мех туннарны тагын һәм тагын! Сыйфатны да яхшы итегез, — күтәрерлек булсын ил данын.* Ә. Исхак.

8. Кемне дә булса югарырак эш урынына кую. [*Маликов:*] *Нуриеваны өлкән оператор итеп күтәрдек.* А. Әхмәт. [*Шамил:*] *Хәзергә без сезне аэродромга инструктор итеп күтәрергә торабыз, диләр.* Т. Гыйззәт. || Нинди дә булса яктан югарырак дәрәҗәгә күтәрү. *Шагыйрьне шәһәр күтәрде, шуңа күрә дә ул аннан бизми.* Г. Нигъмәти. [*Зифа:*] *Тик колхозлы еллар Безне шушылай өскә күтәрде.* Ш. Маннур.

9. Кемнең дә булса карашында, фикерендә берәр кешене тагын да ихтирамлырак, абруйлырак итү. *Бу хәл үзе генә дә Газинур каршында Морозовны бик югары күтәрде һәм ул кайчан да булса аның белән якыннан дуслашуына да ышана иде.* Г. Әпсәләмов.

10. Югарырак, камилрәк итү, аң-белем, культура дәрәҗәсен үстерү. *Революциягә кадәр иң кабахәт шартлар эчендә эшләп килгән эшчеләргә, шулар эчендә татар эшчеләренә, үзләренең аң-белемнәрен күтәрүгә, үзләрен сәяси үстерүгә, әлбәттә, мөмкинлек булмагандыр.* Һ. Такташ.

11. Нинди дә булса эш-хәрәкәткә кузгату, җилкендерү. *Татар буржуазиясенең „милли азатлык" турындагы бу сөйләнүләре бервакытта да изелүче милләт халкын самодержавиегә каршы күтәрү теләген күздә тотмадылар.* М. Җәлил. *Бу шигырьләр сыйныф көрәше дәрте белән тулганнар, боларда көрәшкә күтәрү дә, аңа чакыру да бар.* Г. Нигъмәти.

12. Күтәренке итү, шатландыру; яхшы тәэсир итү (рухка, күңелгә, кәефкә һ. б.). *Рухны күтәрү.* □ *Мин, аның күңелен күтәрерлек бер-ике җылы сүз әйткәннән соң, ашыгып, авылга таба йөгердем.* А. Шамов.

13. Кичерү, баштан үткәрү; түзү (авырлыкларга һ. б. ш.). *Золым, җәбер вә кыенлыкларны күтәрәләр шул кешеләр ки, кайсылары кан-тирләргә батып эшлиләр — хезмәт итәләр.* Г. Тукай. *Бер ишләре, юл михнәтен күтәрә алмыйча, үлеп калганнар.* К. Нәҗми. [*Ильяс:*] *Тик бу авырлыкны мин кешегә сиздермичә генә күтәрергә тырыштым.* М. Әмир.

14. Авырсынмыйча кабул итү, үз өстенә алу; кичерү, үткәреп җибәрү. *Кала килмешәгенең авыл матурларына кагылуын авыл яшьләре, әлбәттә, күтәрмәсләр, бер җаен табарлар да аның кабыргаларын санарлар.* Г. Ибраһимов. *Авыру анасын ташлап читкә китүне аның вөҗданы күтәрмәде.* Г. Бәширов. || Үз өстенә алу, түләү (расходны). [*Егет:*] *Ул терелеп аякка басканчы, сезгә аның бөтен расходын күтәрергә туры килер.* А. Шамов.

15. Кайбер исемнәрдән соң килеп, шул исем белдергән эш-хәрәкәтне китереп чыгаруны, шул эш-хәрәкәтне үти, башкара башлауны аңлата. [*Нәгыйм:*] *Халык җәнҗал күтәрмәгәй иде, дим.* Ш. Камал. [*Миронов:*] *Шундый шау-шу күтәрерлек нинди яңалык чыгардың син анда.* Р. Ишморат.

16. Яхшырту, торгызу, юлга салу (хуҗалыкны, аның тармакларын). *„Киләчәккә хатлар" --- авылда колхоз төзү һәм завод-фабрикада социализм ярышын алып баруны, промышленностьны күтәрүне сурәтли.* Г. Нигъмәти. [*Егет:*] *Без күмәкләштерелгән авыл хуҗалыгын тагын да күтәрергә, колхозчыларны таза тормышлы итәргә --- тиеш.* А. Шамов.

17. Сөрү, эшкәртү (парга калдырылган яки чирәм җирне). *Пар күтәрү.* □ *Алтын бодай дулкынлана Без күтәргән чирәмдә.* З. Мансур.

18. Берәр кеше яки нинди дә булса эш-хәл хөрмәтенә эчү; тост әйтеп эчү. [*Рәшит:*] *Мин, иптәшләр, әнә шундый әкият кебек матур киләчәк өчен тост күтәрергә тәкъдим итәм.* Р. Ишморат. *Саф мәхәббәт хөрмәтенә күтәрик бокалларны.* Ә. Ерикәй. || *сөйл.* Гомумән аракы эчү. *Разведчикларның кәефләре аеруча күтәренке иде. Алар операциядән соң үзләренә бирелгән йөз иллешәр грамм аракыны кружкаларга салып күтәрделәр.* А. Әхмәт.

19. *сөйл.* Йөртү, ия булу (берәр төрле исемгә, дәрәҗәгә). [*Депутат:*] *Дгәр бу мәсьәлә милләт телләгәнчә хәл ителмәсә, --- безгә депутат исемен күтәрүдә мәгънә калмый.* Ш. Камал. || Йөкле булу, карында тума йөртү. *Тугыз ай бала күтәрү.*

20. *махс.* Санны яки алгебраик аңлатманы күрсәтелгән мәртәбә үз-үзенә тапкырлау. *Вакланманы дәрәҗәгә күтәрү өчен, санаучыны һәм вакларучыны аерым-аерым шул дәрәҗәгә күтәрергә һәм беренче нәтиҗәне икенчесенә бүләргә кирәк.* Алгебра.

21. *с. мәгъ. махс.* Күтәрү эше белән бәйләнгән, күтәрә торган, күтәрү эшенә караган. *Күтәрү механизмы. Күтәрү көче. Күтәрү машиналары.* □ *Күтәрү краны ярдәмендә бер урыннан икенче урынга күчерелә торган йөкнең хәрәкәте, --- транспортер тасмасына салынган әйберләрнең хәрәкәте --- йөреш хәрәкәтенә мисал була.* Физика.

◇ **Күтәреп алу** — бик теләп каршы алу, зур теләк белән каршы алу; хуплап каршы алу. *Карарны педсовет та, колхозның комсомол оешмасы да хуп күрде, ә класс җитәкчесе Тәзкирә апа күтәреп кенә алды.* Г. Гобәй.

КҮЧ I *и.* 1. Ана кортка ияреп аерым бер төркем рәвешендә булып бүленеп чыккан бал кортлары семьясы. *Бер корт анасын тоткан бөтен күчен тотар.* Мәкаль. *Агач башларына сарган күчләрне тубалга тутырышуда этигә ярдәм итүләр тагын да күңелле иде.* М. Гафури.

2. *сөйл.* Бер төргә караган вак хайваннар төркеме. *Бәке ачкан җирдә тере балык күче йөргәне күренми әле.* Г. Ахунов.

3. *иск.* Күченеп баручы ил, авыл (кабилә, төркем). *Арбам сынды дип күчтән калма, башым авырта дип эштән калма.* Мәкаль.

Күч аеру — башка анага кушып яңа бер яшь семья аерып чыгару (бал кортлары турында). *Кайбер умартачылар умарталыкта корт семьяларының күч аеруларын көтеп тормастан, ясалма рәвештә күч аеру юлын куллан[алар].* Умартачылык.

КҮЧ II *и. сөйл.* Өем. [*Кызлар кәбестәләрне*] *бергә җыеп, күчкә өя баралар.* Г. Ахунов.

КҮЧЕМЛЕ *с. лингв.* Эш яисә хәрәкәтнең төшем килешендә тәгъбир ителгән объектка күчүен белдерә торган. *Эшнең, хәлнең нинди дә булса предметка күчүен белдерә торган фигыльләр күчемле фигыльләр дип йөртеләләр.* Татар теле грамматикасы.

КҮЧЕМЛЕЛЕК *и. лингв.* Күчемле булу (фигыль турында). *Күчемлелек фигыльнең туры объект телләве (соравы), күчемсезлек исә анда әнә шундый таләпнең сизелмәве белән билгеләнә.* В. Хангилдин.

КҮЧЕМСЕЗ *с. лингв.* Үзеннән соң килгән тәмамлыкның төшем килешендә булуын таләп итми торган. *Эшнең, хәлнең нинди дә булса бүтән предметка күчүен белдерми торган фигыльләр күчемсез фигыль дип йөртеләләр.* Татар теле грамматикасы.

КҮЧЕМСЕЗЛЕК *и. лингв.* Күчемсез булу (фигыль турында). *Татар телендә күчемлелек-күчемсезлек грамматик категория була алмый.* Д. Тумашева.

КҮЧЕНҮ *ф.* 1. Барлык кирәк-яракларны алып бер урыннан икенче урынга күчү. *Ставканың боегысын үтәп, төнге караңгылыкта гаскәрләр ашыгыч рәвештә бер урыннан икенче урынга күченде.* Г. Әпсәләмов. [*Сафа:*] *Халык Ябалак тавына күченә. --- Түбән оч күперен агызып киткән.* К. Тинчурин.

2. Башка бер яшәү (тору) урынына күчү; башка өйгә яки квартирага күчү. *Без күчендек иске йорттан.* Н. Исәнбәт. *Бүген алар яңа өйгә күчену көнен шатланып бәйрәм итәләр.* А. Алиш. || Күчмә тормыш алып барганда бер урыннан икенче урынга күчү. *Шул далада, шул шатлыклы күченүләр, шау-шулы маллар эчендә кайнап, ашлык сугып --- Калтай белән Карлыгач үсеп буйга җиттеләр.* Г. Ибраһимов.

3. *и. мәгъ.* Акрынлап үзгәрү; күчеш. *Акрын, бик акрын башланган музыкаль тавышлар йомшак, ягымлы күченүләр белән зур зилзиләләргә җитә ... тына ... тагын күтәрелә.* Г. Кутуй.

КҮЧЕРГЕЧ *и.* 1. *сөйл.* Өлге, үрнәк (чигү, тегү эшендә).

2. *күч. иск.* Башкаларга үрнәк булырлык нәрсә, үрнәк булырлык өлге. [*Рәстәм:*] *Орденнарны --- зур батырлыклар күрсәткән өчен бирәләр; колхозларда, завод-фабрикаларда бөтен кешеләр өчен күчергеч булырлык зур эшләр эшләгән өчен бирәләр.* Г. Гали. [*Сарыбай:*] *Менә, Актырнак дус, бер кулыңны, без икәү кыяматкә кадәр аерылмаска дус кушылыйк һәм үзебездән соңгыларга да күчергеч булыйк.* Г. Тукай.

3. *тех.* Әйләнү хәрәкәтен җайланманың бер өлешеннән икенче өлешенә күчерү механизмы. *Гидравлик күчергеч. Тешле күчергеч. Чылбырлы күчергеч.*

4. *тех.* Нәрсәнең дә булса эшен, хәрәкәтен үзгәртүче җайланма. *Диапазоннар күчергеч. Электр күчергече.*

5. *с. мәгъ.* Күчермә алу өчен хезмәт итә торган. *Күчергеч кәгазь.*

Күчергечләр тартмасы *тех.* — тизлекне үзгәртү механизмы (автомобиль, трактор һ. б. машиналарда). *Автомобильләрдә һәм тракторларда төрле тизлек булдыру өчен күчергечләр тартмасы кулланыла.* Физика.

КҮЧЕРЕЛМӘ *с.* 1. *махс.* Нинди дә булса башка зурлыкларда, күрсәткечләрдә чагылдырылган. *Тулай продукция --- күчерелмә шартлы берәмлекләр (мәсәлән, азык берәмлекләре, калорияләр) белән күрсәтелергә мөмкин.* Соц. Тат.

2. *лингв. сөйл. к.* күчермә *(3 мәгъ.). Сүзнең күчерелмә мәгънәсе.*

КҮЧЕРЕЛМӘЛЕ *с.* Күчерелә торган, күчерелү өчен җайланган. *Күчерелмәле лампа.*

КҮЧЕРМӘ *и.* 1. Төп нөсхәдән үзгәртмичә, төгәл күчереп алынган нәрсә; копия. *Сызымның күчермәсе.* □ *Каршындагы стенага матур кысалы Репин рәсеме һәм астарак „Бурлаклар"ының киндергә төшерелгән яхшы күчермәсе эленгән.* Г. Бәширов. *Рәис --- [карарларның] күчермәләрен газетага җибәрә барырга куштым.* Г. Ибраһимов.

2. Нинди дә булса текстан күчереп алынган өзек, өземтә, цитата. *Сүз башыннан озын бер күчермә китергән өчен укучы безгә рәнҗемәс дип ышанабыз.* В. И. Ленин.

3. *с. мәгъ. лингв. к.* күчмә I (7 мәгъ.). *Сүзнең күчермә мәгънәсе.*

КҮЧЕРТҮ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* күчерү (14 мәгъ. башка). [*Шәрәфи:*] *Моның өчен [материалларны] ачык итеп күчерттем.* Г. Ибраһимов.

2. Кемгә дә булса рәсми рәвештә тапшыру; кем исеменә дә булса яздыру (милекне һ. б.). [*Гайнулла:*] *Йорт-җиреңне дә хатының исеменә күчертергә кирәк һәм кибеттәге товарыңны да чамалы гына калдыр.* Ш. Мөхәммәдев.

КҮЧЕРҮ *ф.* 1. Берәр предметны бер урыннан алып икенче урынга кую (күтәреп, этеп). *Андагы*

[*юешлеккә*] *сабырым бетеп, өстәлне ишек төбенә күчердем.* Г. Тукай. *Фәридә гөл чүлмәген яктыгарак күчереп куя.* Р. Ишморат.

2. Урнашкан урынын үзгәртү, икенче урынга урнаштыру. *Штабны күчерү.* □ *Мостафа һәм Халикъ белән Ишмай тиз арада учакны күл буеннан монда— алачыкларга якын күчергәннәр.* Ш. Камал. *Бал кортларының ояларын җылы урынга кышларга күчерделәр.* А. Алиш. || Текстта юлга сыймаган сүзнең кисәген, тиешле грамматик кагыйдәләрне саклаган хәлдә, икенче юлга язу. *Соңгы иҗекне икенче юлга күчерү.*

3. Бер урыннан икенче урынга илтү, алып бару (кешеләрне). *Нәфисә кызларны солы җиренә күчереп кайтышлый --- урман эченнән Бикмулла карт килеп чыкты.* Г. Бәширов. *Менә шулар өстенә трамвай һәм автобус йөрешләре өстәлә, алар һәр көнне берничә йөз меңәр кешене Парижның бер җиреннән икенче җиренә күчерәләр.* Г. Гали. || Берәр нәрсә аша чыгару. *Көймәче бу кешеләрне суның арьягына күчергәч тә, куллары белән күрсәтеп, юллар тәгъриф итә иде.* Ш. Камал.

4. Яшәү, тору урынын алыштыру, икенче бер яшәү, тору урынына җибәрү. *Польша белән ике арада килешү көтелгәнлектән, көзгә таба армиянең бер өлешен Врангель фронтына күчерә башлаганнар.* Г. Бәширов. [*Төхфәт:*] *Лазареттан лазаретка күчереп, тинтерәтеп бетерделәр.* Ш. Камал.

5. Нинди дә булса бер эштән азат итеп, икенче эшкә алу, икенче эшкә билгеләү. *Өлкә Комитеты аның соравын тыңлады һәм шушы Камышлыга райкомның икенче секретаре итеп күчерде.* Ә. Еники. *Аны бары икенче цехка гына күчергәннәр.* Г. Ибраһимов. || Бер баскыч югарырак класста яки курста укырга хокук бирү. [*Кыз:*] *Шуның өчен үзеңне класстан күчермәделәрме, бабай? Икенче елны да һаман беренче класста укып йөрдеңме?* М. Гали.

6. Бер нәрсәдән икенче нәрсәгә юнәлтү, юнәлешне үзгәртү (эш-хәрәкәтнең). *Һөҗүмне уң флангка күчерү. Артиллерия утын күчерү.* || Бер нәрсәдән икенче нәрсәгә таба юнәлтү, төбәү (күзне, карашны). *Гали Хәят вә Әминә өстенә күз салды да, аларның үзенә караганлыкларын күргәч, күзләрен тиз генә янындагы кызга күчерде.* Ф. Әмирхан. || Торышын үзгәртү, икенче торышка китерү. *Сәгать угын күчерү.* || *күч.* Сүзгә, әңгәмәгә һ. б. икенче юнәлеш бирү, сүзнең, әңгәмәнең һ. б. юнәлешен үзгәртү; башка нәрсә турында сүз башлау. *Салахиев үз хатасы турында сүзне шуның белән бетереп, сүзне Александра Сигизмундовна әйткән мәсьәләләргә күчерде.* Г. Ибраһимов.

7. Берәр нәрсәнең эшләү режимын үзгәртү. *Тизлекне күчерү.*

8. Нинди дә булса бурыч үтәүне, эш башкаруны икенче вакытка калдыру; кичектерү. [*Приказчик:*] *Суконщиклар узган ел ителми калган пасха бәйрәмен, көзгә күчереп, менә бүген шуны итеп йөриләр.* М. Гали. || Берәр мәсьәлә тикшерүне башка бер җылешка чыгару, башка бер җылешка калдыру. *Якуб мәсьәләне авыл җыенына күчерде.* И. Гази.

9. Банк аша (акча) җибәрү, банк аша башка учреждение счетына (акча) яздыру. *Алган товарлар өчен магазинга акча күчерү.*

10. Оригиналның текстын яңабаштан үзгәртмичә язып чыгу, язып алу; нинди дә булса текстның күчермәсен алу. *Женни Маркс әсәрләрен акка күчергән.* Г. Кутуй. *Әхмәт витринадан Рамазановның еллык планны үтәү күрсәткечен блокнотына күчереп алды.* Г. Минский. || Оригиналдагы рәсемне икенче бер нәрсәгә төшерү, төшереп алу. *Китабымны ачтым, иң беренче Битендәге таныш рәсемне Кәгаземә күчереп төшердем мин.* С. Хәким. || Кем дә булса язган, иҗат иткән нәрсәне яңадан язып, иҗат итеп, үзеңнеке итеп күрсәтү. *Сәйдәш, әлбәттә, халык музыкасына сукыр иярмәде, аларны күчерү белән генә шөгыльләнмәде. Ул аларның өстендә эшләде һәм үзеннән бик күп иҗат байлыгы өстәде.* М. Җәлил. || Башка укучы тарафыннан язылган яки чишелгән нәрсәне язып алып, үзенеке итеп күрсәтү. *Каюм комсызланып бөтен гәүдәсе белән кәгазьгә таба сузылды һәм андагы цифрларны тиз генә күчереп алды да укытучысына бирде.* Г. Гобәй. [*Ирек:*] *Күчереп язып, нәрсәсен аңларсың? Утыр менә, мин хәзер сиңа аңлатып бирәм.* Д. Аппакова. || Кемнең дә булса тәҗрибәсен кабул итү, үзләштерү. *Иген игү алымын күчерү.*

11. *сир. кит.* Бер телдәге текстны икенче телдәге чаралар белән бирү, тәрҗемә итү. *Болар гомумән классик музыканың текстын, шул музыкага тәмам туры китереп, бөтен кануннарын саклап, татарчага күчерүнең иң беренче үрнәкләре иде.* М. Җәлил. [*Г. Камал*], *Октябрьдан соң да әдәби тәрҗемәчелек эшен дәвам иттереп, рус һәм Көнбатыш классикларының күп кенә әсәрләрен татарчага күчерде.* М. Гали.

12. Нәрсәне дә булса башка шартларга кую.— *Тик шунысын ачык беләм: авылны социалистик нигезгә күчерү өчен хәзерге аерым-аерым вак хуҗалыкларны берләштереп, әре хуҗалыкка әйләндерү кирәк.* М. Әмир.

13. Нәрсәнең дә булса характерын үзгәртү; нәрсәне дә булса (мәсәлән, кыйммәтне) башка күрсәткечләрдә чагылдыру. *Картаны зур масштабка күчерү.* □ [*Вәлишин:*] *Күчер алтынга мал-мөлкәтеңне.* К. Нәҗми.

14. *и. мәгъ. шигъ.* Шигырь төзелешендәге бер алым: фразаның, җөмләнең ахырын бер шигырь юлыннан икенчесенә күчерү (мәсәлән:

Авырганда, үлем кочагына
Үзен атып, сине яклаган. Һ. Такташ).

Күчереп утырту. а.-х. — 1) үсемлекне, бигрәк тә яшелчә үрентесен, казып алып икенче урынга утырту. *Кыярны күчереп утырту.* □ *Ташкабакны, --- тамырын имгәтмичә, туфрагы белән алып яки торфчеремә чүлмәкләрдә, кәгазь стаканнарда ачык грунтка күчереп утырталар.* Җиләк-җимеш...; 2) берәр әгъзаны (мәс, йөрәкне) кисеп алып икенче организмга кую. *Күчереп утырту өчен органнарны сәламәт кешедән алу бик катлаулы һәм җитди эш.* Соц. Тат. **Күчереп язучы** — *к.* күчерүче. **Күчереп ялгагыч** *тех.* — нәрсәнең дә булса эш характерын (юнәлешен, көчен һ. б.) үзгәртү өчен хезмәт итә торган җайланма; *русчасы:* переключатель. **Күчереп ялгау** *тех.* — берәр нәрсәнең (газ агынтысы, электр тогы һ. б. ш. ның) хәрәкәт итү юнәлешен үзгәртү, бер юнәлештә хәрәкәт итүен туктатып, икенче юнәлешкә күчерү. *Электр чылбырында токны күчереп ялгау.*

КҮЧЕРҮЧЕ *и.* Текстларны күчереп язу белән шөгыльләнүче кеше.

КҮЧЕШ *и. махс.* Бер сыйфаттан икенче сыйфатка күчү; бер нәрсә үзгәреп икенче нәрсәгә әйләнгән момент, урын; берсе икенчесенә әйләнгән күренешләрне бәйләүче момент. *Музыкаль әсәрдәге кискен күчешләр.*

КҮЧЕШСЕЗ *с. махс.* Күчми торган; акрынлап күчә бармый торган. *Иске төр яңа төрне бернинди күчешсез һәм ара формаларсыз гына китереп чыгара.* Биология.

КҮЧМӘ I *с.* **1.** Бе́р урыннан икенче урынга күчеп йөри торган, хәрәкәттә булган. *Күчмә саранча — культуралы үсемлекләргә зарар китерә торган кур-*

кыныч.лы корткыч. Зоология. *Куктә аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме.* Г. Тукай.

2. Утрак тормыш алып бармый торган, бер урыннан икенче урынга күчеп яши торган. *Күчмә кабилә.лар.* □ *Борынгы күчмә халыклар арасында үзара өзлексез сугышлар дәвам иткән.* М. Җәлил. || Бер урыннан икенче урынга торак һәм мал-мөлкәт белән күчүгә бәйләнешле. *Күчмә хуҗалык. Күчмә тормыш.* || Халыкның утрак тормыш белән яшәгәнгә кадәр булган дәверенә караган. *Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык.* Г. Тукай. || *и. мәгъ. күпл.* Күчмә тормыш алып барган кешеләр, күчмә тормыш белән яшәгән халык. [*Солтангәрәй:*] *Ялланам да күчмәләргә, Бу шәһәрне мин ватам.* Н. Исәнбәт. [*Болгарга*] *Алтын Урда ханнары, дала күчмәләре әледән-әле һөҗүм итеп торалар.* Каз. утл.

3. Кышын көньяк илләргә очып китә торган (кошлар турында). *Күчмә кошлар.*

4. Хәрәкәт итә ала торган, төзелеше хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирә торган (җайланмалар, механизмнар турында). *Күчмә кран. Күчмә блок.* □ *Кәтүкләр арасына кәгазьдән эшләнгән күчмә балдак киертелә, аңа кайтма бәйләнеш кәтүге урала.* Радио сөюче...

5. Үзенең эшен даими бер урында алып бармаган, эшен бер урыннан икенче урынга күчеп башкара торган. *Күчмә китапханә. Күчмә күргәзмә.* □ *Район күчмә театрыннан бүре һәм шүрәле костюмнары сорап алып кайттылар.* Г. Гобәй. || Күчереп йөртү өчен тәгәрмәчләргә утыртылып, нинди дә булса хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән. *Чыннан да, үргә күтәрелүгә, стан күренә. Бирге почмакта — күчмә кухня.* И. Салахов. || Даими урыннан кайда да булса читтә үткәрелгән (башкарылган). *Райсоветның күчмә сессиясе.*

6. Нинди дә булса ярышта өстен чыккан яңа җиңүчегә бирелә торган. *Күчмә кубок.* □ [*Айсылу:*] *Партиянең район комитеты, районның башкарма комитеты яхшы эшләвебез, бодайдан зур уңыш алуыбыз өчен бүгенгесе көнне безгә менә шушы күчмә Кызыл Байракны тапшырдылар.* Г. Бәширов.

7. *лингв.* Туры булмаган, төп мәгънә булмаган (сүзнең мәгънәсе турында). *Сүзнең күчмә мәгънәсе.*

Күчмә мөлкәт *экон.* — буржуаз хокукта: җир белән турыдан-туры бәйләнмәгән һәм күчереп була торган мөлкәт (җиһаз, төрле әйберләр һ. б.).

КҮЧМӘ II *и. диал.* Су аша салынган басма. *Күчмә өстеннән су алганда, Башмакларым чыланганга, Салып куйган идем шунда — Оныткамын башмагымны.* Җыр.

КҮЧМӘЛЕ *с. к.* күчмә I (2 мәгъ.). *Ак бүкәнне чатыр димә, күчмәлегә утыр димә.* Мәкаль.

КҮЧМӘЛӘҮ *ф. диал.* Бал әчетергә кую, бал кою. — *Вакытында колмагын да, салатын да таба алмаганга, без бу ел күчмәләп маташмаган идек, гаеп итмәгез инде, егетләр.* М. Гали.

КҮЧТЕРӘ *и. диал.* Кыяклылар семьялыгыннан чүп үләне, сарут; *русчасы:* костёр.

КҮЧТӘНӘЧ *и.* Хөрмәт йөзеннән яки бүләк итеп китерелә яисә җибәрелә торган ашамлык. *Иң элек кодаларның ашларын, туй күчтәнәчләрен мәҗлескә чыгарып күрсәттеләр.* Г. Ибраһимов. *Газинур алып кайткан шәһәр күчтәнәчләрен дә табынга куйдылар.* Г. Әпсәләмов. | *с. мәгъ. Балалар ул сөйлгәндә, күчтәнәч конфетларын учларына кысып, тын гына утырдылар.* Г. Гобәй.

КҮЧӘ *и. иск.* Урам, кечкенә урам. *Соңгы нурлар Төрле тыкрыктан үтеп, Тар күчәләрдән, Өйдән, Землянкадан Портка кудылар Халкын бер итеп.* М. Җәлил.

КҮЧӘН *и.* Кәбестә сабагы. *Кәбестә күчәне.* □ *Бу кәсеп фәкать иң соңгы яшелчә булган кәбестәләр җыелып алынганнан соң гына, аларның да җирдә утырып калган күчәннәренә чаклы йолкынып беткәч кенә тәмам була.* М. Әмир.

КҮЧӘР *и.* 1. Агачтан яки металлдан ясалып, башларына тәгәрмәчләр кидерелә торган үзәк. *Вагон күчәре.* □ *Анда берничә колхозчы тәгәрмәч бүкәннәре кырып, тугымнар эшләп, колхоз арбаларына тәгәрмәчләр һәм күчәрләр ясап яталар.* М. Гали. || *тех.* Механизмнарның әйләнә торган өлешен тотып тора торган деталь. *Кузгалмас күчәр.*

2. *махс.* Нинди дә булса җисемнең яки пространствоның үзәгеннән үтә торган уйланма туры. *Җирләнү күчәре. Координаталар күчәре.* □ *Айның күчәр тирәсендә әйләнү периоды нәкъ аның Җир тирәсендә әйләнеп чыгу периодына тигез.* Астрономия. *Менә бу тапларның шулай күчеп йөрүләре Кояшның да безнең Җиребез кебек үз күчәре тирәсендә әйләнеп торуын белдерәләр.* Ф. Әмирхан.

Күчәр тимере — арба күчәре астына күчәр тиз тузмасын өчен куелган тимер.

◇ **Күчәр башлары эләгешү** — тиргәшү, ачуланышу.

КҮЧӘТ *и. диал.* Күчереп утырту өчен хәзерләнгән яшелчә үрентесе.

КҮЧҮ *ф.* 1. Бер урыннан китеп икенче урынга бару (килү), барып (килеп) урнашу. *Шул ук кич, караңгы төшкәч, яңа килгән - - - роталарга алдынгы линия окопларына күчәргә приказ булды.* М. Гали. || Урын алыштырып, кемгә яки нәрсәгә дә булса елышу, якынлашу. *Әхмәдулла аның янынарак күчеп утырды да шыпырт кына һәм серле генә әйтте.* А. Шамов. || Бер нәрсәдән икенче нәрсә янына килү; килеп утыру. *Арбадан пароходка, пароходтан поездга күчә-күчә эштән чыккан бичара ахыры бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым.* Г. Тукай. *Ә безнең Нечкәбил башка чәчәккә күчә.* А. Алиш. || Нинди дә булса пространство яки берәр нәрсә аша икенче якка чыгу, үтү. [*Галләметдин*], *боз аркылы күчеп, тау сукмагы белән шәһәр ягына үрмәләде.* Ш. Камал. || Нинди дә булса эш-хәрәкәтнең таралуы, җәелүе турында. *Янгын шрапнель вагоннарына, аннан артиллерия складларына күчә.* К. Нәҗми. *Сугыш дәһшәте бу батыр шәһәрнең урамнарына күчте.* Г. Бәширов.

2. Берәр яшәү, тору урынын ташлап башка урынга барып урнашу. [*Фатыйма*] *утыз ел буена димләп тә ирен калага күчәргә күндерә алмагач, ичмаса, балам бу җәһәннәмнән котылсын дип, Мәрьямне гимназиягә бирергә ижтиһат кылган иде.* Г. Ибраһимов. *Гафиятулла абзый авыл халкының бер өлеше белән Бөгелмә районына күчәргә ризалыгын белдерә.* Г. Әпсәләмов. || Бер торган өйне, квартираны калдырып башка өйгә, квартирага керү, кереп урнашу. *Сафа үзенең карчыгы белән һидият өенә торырга күчте.* Ш. Камал. *Көннәрдән бер көнне ана белән кыз, яңа йортка күчмәкче булып, йорт әйберләрен ташый башлаганнар.* Д. Аппакова || Күчмә тормыш алып барганда тору урынын үзгәртү; үзенең торагы һәм мал-мөлкәте белән икенче урынга торырга китү. *Сарсымбай иртә таңнан яңа җәйләүгә — Кызыл-комга күчәчәк булганга, үзара аңлашу мәҗлесен җомга көнгә кичектерделәр.* Г. Ибраһимов.

3. Бер эш урыныннан чыгып икенче эш урынына керү; эшләү урынын алыштыру, хезмәтне алыштыру. *Эшче, бу завод-фабрикаларның берсеннән икенчесенә күчеп йөргән булса да, егерме-утыз еллар эшләгән.*

Г. Нигъмәти. *Бер хатында ул инде зениткада тугеллеген, әдесант отрядына кучкәнлеген һәм тиздән операцияләр башлану мөмкинлеген яза.* И. Гази. || Нинди дә булса классны, курсны тәмамлап, бер баскыч югары класс яки курс укучысына әйләнү. *Гөлсем апа, имтиханнарны биреп бетереп 4 нче курска күчүгә, Наркомпроска китте.* Г. Гобәй. [*Бабай:*] *Мин әле һаман беренче класста, син быел гына укый башласаң да миннән алга киттең, икенче класска күчтең, кызым.* М. Гали. || Бер диннән чыгып башка динне кабул итү. *Католик диненә күчү.*

4. Эш итү рәвешен үзгәртү, башкача эш итә башлау. *Хозрасчетка күчү. Бишкөнлек эш атнасына күчү.* □ [*Вәли Хәсәнов:*] *Мин өч басудан күп басуга күчтем.* Г. Ибраһимов.

5. Берәр төрле эш-хәрәкәтне тәмамлап яки калдырып икенче бер эш-хәрәкәтне башлау. *Икенче темага күчү.* □ [*Бикташев:*] *Инде икенче мәсьәләгә, социализм ярышы һәм ударчылык мәсьәләләренә күчәбез, иптәшләр.* Ш. Камал. [*Ибрай*] *әле бер әйберен күрсәтә, әле икенчесен күрсәтә, бакчасының тәртиплелеген, яшелчәләренең шәплеген мактап бетергәнебезне дә көтми, яңа әйберләргә күчә.* М. Әмир.

6. Кемнең дә булса милкенә әйләнү, милке булып калу; кемнең дә булса карамагына бирелү. *Һәммә җирләр халык кулындагы земстволарга бушлай күчәргә тиеш.* Урал. *Җир һәм власть халык кулына күчәргә тиеш.* К. Нәҗми.

7. Сугышучы якларның берсе тарафыннан алыну (торак пункт, объект һ. б.). *Сәгыйдә яшеренеп кенә урамга чыгып кергән атасыннан кызылларның чигенүләрен, авылның аклар кулына күчүен ишетте.* Һ. Такташ.

8. Бер урыннан икенче урынга китерелү (әйбер турында). [*Тимери*] *чүмәләдәге иген ындыр эченә күчеп беткәнче, шушы ярсу эше белән бүтәннәрне дә ялкынландырып, ике арада өермәдәй бөтерелеп йөрде.* Г. Бәширов. || Әйбернең бер кеше кулыннан икенче кеше кулына керүе турында. *Трубка шулай кулдан-кулга күчеп чыкканнан соң гына, карчык, сәкедән төшеп, кара якка чыгып китте.* А. Шамов. *Кәгазь кулдан-кулга күчкән арада, Якуб Дәүләтьяровның ач яңаклы какча йөзенә тагын бер тапкыр карап алды.* И. Гази. || Сүз, хәбәр һ. б. ш.ны бер кешенең икенче кешедән ишетеп сөйләве, әйтүе турында. *Берме, икеме кешенең колагына салынган бу сүз яшен тизлеге белән телдән телгә күчә.* Ә. Фәйзи. *Исәнме, Байкал, --- Телдән телләргә Күчеп йөргән күл!* Ш. Маннур.

Күчеп утыру — элек яшәгән урынны калдырып яңа җиргә килеп урнашу, тормыш кору. *Күп еллар элек Сакмар суы буендагы Петровка авылыннан Иван Чуркин дигән кеше берүзе монда күчеп утырган.* Ш. Камал. **Күчми торган мөлкәт** *экон.* — буржуаз хокукта: җирдән һәм корылмалардан (биналардан) гыйбарәт мөлкәт.

КҮШЕГҮ *ф.* Суыктан яки салкын яңгырдан хәрәкәтчәнлекне югалту, тою сәләте кимү (мәсәлән, кул яки аяк). *Күшеккән кул-аяклар тәмам сизмәс хәлгә килеп, бу кәһәр төшкән юлның һәм караңгылыкның очы да, кырые да юктыр кебек тоела.* Р. Төхфәтуллин. *Әгәр кулларым күшексә,* [*дуслар*] *Кулларымны уалар.* Ә. Ерикәй. || Суыктан яки салкын яңгырдан өшү, калтырап тору. *Мин хәтерлим: карлы, өермәле Салкын кышта туңып, күшегеп, Ун чакрымнан ялгыз җәяү килеп, Мин шакыдым райком ишеген.* М. Җәлил. *Ул төнге кунак иптәшенең яңгырлы, суык җилдә күгәргән иреннәренә, күшегүдән вак сары йон калыккан кәрарак шадра йөзенә карады.* Г. Ибраһимов.

КҮШЕК *и. иск. к.* кресло. [*Хәйбүш Хуҗаны*] *киредән күшеккә утыртып, чаршауны яба.* Н. Исәнбәт.

КҮШЕК-САРАЙ *и иск.* Юлчылар туктый торган кечкенә бина. *Аларга каршы якта түбәсе яссы кечерәк бер күшек-сарай: патшалар, хөкем кешеләре төшү урыны.* Н. Исәнбәт.

КҮШЕКТЕРГЕЧ *с.* Күшектерә торган. *Урамда шыксыз караңгылык һәм күшектергеч вак яңгыр гына иде.* А. Расих.

КҮШИЛ *и. диал.* Юкәдән яки баудан үрелгән савыт.

КҮШЛЕ: күшле чана — киез, чыпта һ. б. ш. белән тышланган биек артлы тирән чана. *Буран иде. Ишек алдына ямщик та зур күшле чанага пар алаша җигеп килгән иде.* Г. Газиз.

КҮШӘ I *и. махс.* Туку станында буй җепнең койрыктан (7 мәгъ.) соң махсус элмәкләү юлы белән үрелгән өлеше, туку процессында әкренләп сүтелә бара.

Күшә баганасы — күшә күзен эләктереп куя торган баганачык.

КҮШӘ II *и. диал.* Көпшә, балтырган көпшәсе. *Урман буенда күшә, су буенда кыр суганы, җир җиләге очрый.* М. Мәһдиев.

КҮШӘГӘ *и. иск.* Җилән, бөркәнчек. *Кигән ыштанны кем күрә, Күшәгәне ил күрә.* Мәкаль.

КҮШӘК *и. иск.* Баганаларга гына утыртылган яки бер яктан стенасы булмаган җиңел конструкцияле, гөмбәз сыман түбәле корылма. *Урамнан, күшәк артыннан, Гөлбикә әбинең бишек арбаны этәреп килгәне күренә.* Н. Исәнбәт.

КҮШӘЛӘҮ *ф.* Туку станындагы койрыкка кадәр булган буй җепне элмәкләп үрү, күшә ясау.

КҮШӘМ *и. махс.* Күшәүче хайваннарның ашказаныннан кире китерелеп, икенче мәртәбә чәйнәлгән азык.

КҮШӘНҮ *ф. сөйл.* Чәйнәү, ашау. *Түшәге бар түшәнер, икмәге бар күшәнер.* Мәкаль.

КҮШӘРЕЛҮ *ф. диал.* Ташып, ургылып, бик көчле булып агу турында. *Габидуллинның бот итен зур гына мина китеге умырып алды. Күшәрелеп кан ага башлады.* Ш. Маннур.

КҮШӘҮ *ф.* 1. Ашказанындагы азыкны кире чыгарып, урт тешләр белән яңадан чәйнәү (күшәүче хайваннар турында). *Төн буе күшәп яткан терлектуарлар да, урыннарыннан торып, иренеп кенә киереләләр.* А. Шамов. || Гомумән чәйнәү. *Иртәнге өлешләрен алган сыерлар, койрык очларын уңга-сулга селеккәләп, юеш саламны ашыкмыйча гына, озак кына күши-күши ашыйлар.* Ә. Еники.

2. *гади с. кимс.* Ашау. *Баем, баем, бай кеше, Җимерелеп бара һәр эше, Ул да кара икмәк күши.* Г. Камал.

КҮШӘҮЧЕЛӘР *и. күпл. зоол.* Партояклы хайваннарның ашаган азыгын кире чыгарып чәйни торган бер төркеме. *Сыер күшәүчеләргә керә.*

КҮӘС *и.* Камыр әчетү өчен савыт. *Дөнья булгач, бала ипи күсән бер пычратмый булмый ул.* Мәкаль.

Күәс төбе — күәс төбендә ачыткы өчен калдырылган камыр.— *Менә, Гөлҗамал абыстай, бу—хәер икмәге, күәс төбен сиңа дип атап әвәлгән идем.* М. Гали. **Күәс чиләге** — *к.* күәс. *Икмәк камырын кую алдыннан онны бик яхшылап иләргә, күәс чиләген чиста итеп юарга кирәк.* Хал. ашлары.

◇ **Күәс төбен кагу** — бөтен эч серен сөйләп бирү.

КҮӘШНӘ *и. сөйл. к.* күәс. *Бер пешкән икмәк бер күәшнә камырдан яхшы.* Мәкаль.

КҮЖӘ *и. этн.* Бодайны киледә төеп ваклаганнан соң казанда яки чуенда кайнатып пешерелгән сыек ботка. *Катык, әйран, эремчек, күжә белән төрлетөрле савытлар, зур-зур казаннар шунда ук урын алдылар.* Г. Ибраһимов. *Сәет күжәне бер-ике йотып тәмләп карады.* И. Салахов.

КҮҢЕЛ *и.* 1. Кешенең эчке, рухи дөньясы; аның кичерешләре, хис-тойгылары. *Кеше күңеле — караңгы төн.* Әйтем. [*Профессор:*] *Күңелнең илаһи бернәрсә түгеллеге, бәлки реаль физиологик күренеш булуы, нервларның иң югары эшчәнлеге, кешенең психикасы икәнлеге хәзер сезнең һәрберегезгә билгеле.* Г. Әпсәләмов. [*Сабит:*] *Табигать миңа шундый бер күңел биргән, ямь, нәфасәт алдында бөтен дөньямны онытам.* М. Фәйзи. || Кешенең хисләре, рухи үзенчәлеге; аерым шәхескә хас үзенчәлекләр. *Ана күңеле. Бала күңеле.* □ *Аның тәкәббер күңеле хәзер инде үзен бер мәртәбә күздән төшкән --- кешегә саный.* Г. Бәширов.

2. Кешенең кичерешләре, хисләре, тойгылары чыганагы. *Аның күңелендә Закирга каршы ачу хисе кузгалды.* Ф. Әмирхан. *Узен сынап йөри торгач, күңелендә туган хиснең чын булуына ул, ниһаять, ышанды.* Ә. Еники. || Интуиция, сиземләү сәләте. *Мостафа, башка бик күп эшчеләр төсле үк, бу афәтнең шомлы сәбәпләре турында аныкбер хәбәр белмәсә дә, күңеле белән сизенеп әйтте.* К. Нәҗми. *Бу ике көчнең соңгысы җиңәчәген күңелем белән бик ачык сизсәм дә, мин сүзсез генә бирелергә теләмәдем.* М. Әмир.

3. Фикер, уй; аң. *Фәхринең кем кулыннан үтүе турында күңелләрдә шөбһә бик кайный иде.* Г. Ибраһимов. *Якубның гади һәм хак сүзләре аларны шикшөбһәдән арындыра, күңелләрендә өмет үрләтә һәм йөрәкләренә кыюлык сала иде.* И. Гази. || Зиһен, хәтер. *Сезнең исемегезне күңелебездә Шушы көнгә чаклы сакладык.* М. Гафури. *Инде карт кешенең биргән киңәшләрен Өстән генә укып үтмәгез, Күңелегезгә алып бикләгез!* Һ. Такташ.

4. Кәеф, рух. *Нәкъ шушы көн һидият бик төшенке күңел белән кайтты.* Ш. Камал. *дәе, капкадан кергәндә Хәлимнең күңеле күтәренке иде.* Г. Гобәй.

5. Мәхәббәт, сөю хисе, ярату хисе. [*Сакчы:*] *Аның күңелен Таһир аулаган.* Ф. Бурнаш. *Кыз чибәр иде ---. Ул чагында аңа гыйшык тотып йөрүче егетләр дә аз түгел иде әле. Сибгать дусның да күңеле бар иде анда.* А. Шамов.

6. *рәв. мәгъ.* **күңеленнән.** Эченнән, уеннан; уйда, анда. *Җамали карт күңеленнән рәнҗеп калды.* Г. Ибраһимов. *Кайгылы өйдә болай шаярып сөйләшүне Мохтар үзе дә күңеленнән яратмады.* Ш. Камал.

7. *рәв. мәгъ.* **күңелдән.** Хәтердән, язмыйча. *Күңелдән исәпләү.* □ *Кушылучыларның урыннарын алыштыру, билгеле, күңелдән эшләнә.* Арифметика. || Яттан. *Һәммә сүзләрен күңелдән белеп бетте.* Г. Ибраһимов. *Алар СССРның көнбатыштагы шәһәр исемнәрен күңелдән ятладылар.* Г. Гобәй.

8. *рәв. мәгъ.* **күңелдә.** Истә, хәтердә. Бу сүз арифметик гамәлләрне чишкәндә язмыйча, икенчесенә кушу өчен калган санга карата кулланыла.

◇ **Күңел азу** — бозык уй-фикерләр, хисләр барлыкка килү. [*Габдулла:*] *Аларның үкертеп йөргәннәрен күреп күңеле азгандыр.* М. Фәйзи. **Күңел азыгы** — күңелне ачу, юату өчен кирәк булган нәрсә, чара; рухи азык. [*М. Горький әсәрендә*] *капитализм шартларында --- эшчегә аз гына күңел азыгы булырлык нәрсәләрнең дә җитәрлек булмавы бик матур итеп, оста гәүдәләндерелеп күрсәтелгән.* Г. Нигъмәти. **Күңел ак булу** — уй-хисләр, теләкләр яхшы булу. [*Акын:*] *Күңелең ак булса, йөрәгеңдә илгә мәхәббәт кипмәсә, син, телсез булсаң да, бүген кайгы җырын көйләрсең.* Г. Ибраһимов. **Күңел алгысу** *диал.* — *к.* күңел ашкыну. *Шуннан соң* [*Шәвәли*], *күңеле алгысып, балта-пычкыга тотына.* Г. Ахунов. **Күңел ачкычы** — 1) кешенең эшчәнлеген нинди дә булса максатка юнәлдерү өчен бирәр төрле юл, алым, чара. [*Айсылу:*] *Ярышны кабындырып җибәрү өчен колхозчының күңел ачкычын табарга кирәк.* Г. Бәширов; 2) күңел ачу чарасы. *Мәзәк — күңел ачкычы, табышмак — зиһен ачкычы.* Мәкаль. [*Хафиз:*] *Күңел ачаргамыни? --- Фазыл, алай булса, чыгар әле күңел ачкычын* [*аракыны*]. Р. Ишморат. **Күңел ачлыгы** — күңел ачу, күңеллеләну өчен мөмкинлек булмауны белдерә. *Хәят кызлык вакытын күңел ачлыгы белән үткәрде.* Ф. Әмирхан. **Күңел ачу** — вакытны күңелле үткәрү, хозурлану, юану. *Пароход килергә шактый вакыт булганга, яшьләр чирәмлектә җырлап-биеп күңел ачалар.* М. Җәлил. [*Сания:*] *Без бүген Идел буена бергәләп күңел ачарга чыктык.* Р. Ишморат. **Күңел ачыклыгы** — эчкерсез, яхшы мөгамәлә; эчкерсез мөнәсәбәт. *Бабай өйләнде. Балаларга башта, бабайның күңел ачыклыгы тәэсире белән, бу эш хуш тоелды.* Ш. Камал. **Күңел ачылу** — яхшы кәеф барлыкка килү, кәеф яхшыру. *Тик Миңнурый җырлый башлагач кына, аның күңеле ачылып китте.* Г. Әпсәләмов. **Күңел ашкыну** — нәрсәгә дә булса бик нык омтылу, нәрсәне дә булса бик нык теләү турында. [*Алтынчәч:*] *Урманга, кырларга Ашкына яшь күңел.* М. Җәлил. *Туган җирләргә, ваемсыз балачак узган илләргә кайтучының күңеле ничек ашкынмасын!* Г. Минский. **Күңел баглау** *иск.* — *к.* күңел(гә) беркетү. **Күңел байлыгы** — кешенең эчке дөньясына хас уй-тойгылар, хисләр. *Мин тагын Разияны якларга керешәм: аның әле бик яшь булуын, шуңа күрә чәчелүен, күңел байлыгын ваклап әрәм итүен --- сөйлим.* И. Гази. **Күңел бару** (күбрәк юклык формасында кулланыла) — теләү, теләк булу, риза булу. [*Хәйретдин:*] *Ай, анасы, бер дә генә күңелем бармый бит бу эшкә. Ничек итеп үз балаңны үзең кара урманда адаштырып калдырырга кирәк.* А. Әхмәт. **Күңел басылу (тынычлану)** — үзен борчый торган уй-хисләрдән арыну, шундый уй-хисләр юкка чыгу; кешедә тынычлык барлыкка килү. — *Әткәй алдында тез чүктереп гафу үтендерсәм, --- шул чакта йөрәгем тынар, күңелем бераз басылыр иде әллә!* Г. Ибраһимов. *Шушы аңлашулардан соң Рәүфәнең күңеле тынычланды.* А. Шамов. **Күңел белән** — 1) эчтән, уйдан, уеннан. [*Солтан:*] *Күңел белән аның урманыннан узасың, чишмәсеннән суын эчәсең, инеш буйларының йомшак чирәмендә йөрисең.* Г. Бәширов; 2) уй-теләкләре белән; йөрәге белән. *Күңеле белән Разияның аяк астына туфрак булырга хәзер торса да, тыштан ул ярлы тәкәббер була.* И. Гази. **Күңел беркетү, күңелгә беркетү** — берәр төрле эш башкарырга карар бирү, берәр нәрсәне эшләргә булу; нинди дә булса бер карарга килү. [*Хөснулла*] *үзе дә Хаҗины ничек тә алтыннар тирәсеннән шуытып җибәрү кирәклекне авылда ук күңеленә бик нык беркетеп куйган иде инде.* Ш. Камал. [*Фатыйма*] *бәя турында инде --- күптән киңәшләшеп, фәлән кадәр сорармын, фәлән кадәр бирсәләр, рөза булырмын дип, бер бәягә күңел беркетеп куйган.* И. Гази. **Күңел биздергеч (кайтаргыч)** — биздерә торган, сөйкемсез; ямьсез. *Ул күзләрдә нидидер күңел кайтаргыч, искәндереп җибәргеч бер нәрсә бар иде.* А. Шамов. *Хәтта* [*Тьерның*] *тышкы кыяфәте дә күңел биздергеч була.* Яңа тарих. **Күңел бизү (кайту)** — нәрсәдән дә булса тую, суыну, бизү; яратмый

башлау, күңел тартмый башлау; кызыксынмый башлау. [*Аларның*] *тормыш кәйфиятләренә чынлап күз салдың исә, ваклыкларын күрәсең,— һәм күңелең дә кайта.* Ш. Камал. *Җирдә тыныч, гамьсез көн итүдән Бизәрмени күңел?* М. Җәлил. **Күңел бирү (кую)**— чын күңелдән тырышу, нинди дә булса эшне бик тырышып башкару. *Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә.* Г. Тукай. *Гимназиядән чыккач,* [*Гали*] *сабын эшенә бигрәк күңел куеп кереште.* Ш. Мөхәммәдев. **Күңел боегу** — *к.* күңел төшү (4 мәгъ.). *Бу караңгы чырайлы кеше янында Сөләймановның үзенең дә күңеле боега башлады, һәм ул Коненкога кырын-кырын карап куйды.* И. Гази. **Күңел бозылу** — кәеф китү, яхшы кәеф юкка чыгу. *Күземә яшь килде, янымдагы --- балаларга: „Китсен, күңелем бозылды", дидем.* Г. Ибраһимов. **Күңел болгану**— 1) косасы килү.— *Бу чайкалудан бик күпләрнең башлары әйләнә, күңелләре болгана.* К. Нәҗми; 2) нәрсәгә карата булса да җирәнү хисе кичерү, нәрсәдән дә булса җирәнү, чиркану. [*Йосыф:*] *Абый урынында мин булсам, бу сүзеңнән әллә кайчан күңелем болгана башлаган булыр иде.* Ф. Әмирхан. **Күңел болгаткыч** — җирәнгеч, чирканыч; начар тәэсир уята торган. *Бу күренеш күңел болгаткыч булды.* Х. Кәрим. **Күңел борчылу** — нәрсә турында булса да хәвефләнеп уйлану, борчылу. [*Гариф Газизәгә:*] *Минем күңелем борчыла, мин сиңе бит чынлап яратам.* Ш. Камал. **Күңел булу** — 1) канәгатьләнү, канәгатьләнү хисе барлыкка килү. *Мортаза абый баш килмәсә дә, Гарифтан алга чыккач, минем күңел булды.* М. Гали; 2) кәеф күтәрелү, яхшы кәеф барлыкка килү. *Күңеле булсын, Рәхмәт әйтсен диеп, Туфля алып кайттым хатынга.* Һ. Такташ. **Күңел бушлыгы** — кешедә бернәрсә белән дә кызыксыну булмау хәле; бернинди дә омтылыш булмау, рухи торгынлык хәле. *Шулай да Нәфисә турында уйлау* [*Зиннәтнең*] *шыксыз күңел бушлыгына ниндидер бер җылылык бирә иде.* Г. Бәширов. **Күңел газабы** — борчылу, рухи борчылу. [*Харис:*] *Аптыраудан, исемә төшмәүгә гажәпләнүдән һәм туып килгән күңел газабыннан телем дә әйләнмәде.* А. Шамов. **Күңел газаплану** — борчылу; борчылу хисе кичерү турында. *Күңеле газаплана башлый* [*Хәлимнең*]. И. Гази. **Күңел даруы** — 1) нинди дә булса күңелсезлекне, бәхетсезлекне кичерергә яки онытырга ярдәм итә торган чара. *Интектерде мине айлар буе Эчем пошуы, йөрәк януы. Кирәк иде миңа тәннән бигрәк Җан даруы, күңел даруы.* М. Җәлил; 2) *ирон.* аракы, спиртлы эчемлек. *Гөлбикә --- бер шешә күңел даруын алъяпкычы астына яшереп урамга чыкты.* Р. Ишморатова. **Күңел дулкынлану** — ашкынулы тынычсызлану, тынычлык югалу. *Бер төрле уйлар дөньясыннан икенче төрле уйлар дөньясына күктән җиргә сикергән шикелле сикерергә туры килгәндә кемнең генә күңеле дулкынланмас икән.* И. Гази. **Күңел жу (шу) итү** — бик нык курку, шүрләп калу. *Тик кинәттән китте күңелем жу итеп. Җир дә җир, сөргән кара җир!* Н. Исәнбәт. [*Зөһрә:*] *Мин тегендә барырга дип чыксам, капка төбенә атлар килеп туктады. --- Күңелем шу итеп китте.* Г. Ибраһимов. **Күңел иләсләнү** — җиңел уйлар барлыкка килү, җилкенү. *Кызның, бичаракайның, күңеле бөтенләй иләсләнеп китә.* Ф. Хөсни. **Күңел йогышу** — *к.* күңел яту. [*Лутов:*] *Ләкин бу халыкка* [*егетнең*] *күңеле йогышып бетми бугай.* Ш. Камал. **Күңел йолдызы** — *к.* күңелнең кәгъбәсе. *Кайда мин, дуслар, хәзер? Ах, кайда күңелем йолдызы?* Н. Исәнбәт. **Күңел йомшару (йомшау, нечкәрү)** — хисләргә бирелеп бик нык тәэсирләнү, әсәрләнү, дулкынлану; дулкынландыра торган хисләр уяну. *Күңелем йомшара, вакытлыча миндә кеҗкенә баладай иркәләнү, назлану хисләре уяна.* Г. Минский. *Күңелем йомшап, абзыйга белдермәскә тырышып кына елап алдым.* М. Гафури. *Бу минутта Нургалинең дә күңеле нечкәреп китте, ничектер, күзләре дымланды, тамак төбе кымырҗып куйды.* Ә. Еники. **Күңел кабул итмәү** — *к.* күңел күтәрмәү (күтәрә алмау). **Күңел кайтару** — биздерү; каршы фикер уяту; яратмаслык булу, ошамау. *Хәер, егетнең төсе-бите дә, кием-салымы да күңел кайтарырлык түгел: башына кепка, өстенә кыска тужурка, аягына кун итек кигән.* А. Шамов. *Бу хәл бригаданың үсешенә ярдәм итми, киресенчә, бораулаучыларның күңелен кайтара иде.* Г. Ахунов. **Күңел калу** — үпкәләү, рәнҗү; хәтер калу. *Ансын алып кайттым, Шәһәр бит, дим, Кеше хуры булып йөрмәсен. Дөнья хәле, күңеле калыр, дидем, Үлеп-нитеп китәр, белмәссең.* Һ. Такташ. **Күңел канатлану** *шигъ.* — нинди дә булса берәр яхшы хис, омтылыш барлыкка килү турында. *Тик бер теләк: сөю дәрте белән Канатланса иде күңелләр.* М. Җәлил. **Күңел капчыгын чишү** — эч серен сөйләү, эч серен ачу. *Улы күңел капчыгын чишәргә ашыкмады, анасының төпченүләрен --- икенче якка борып җибәрде.* Ш. Хөсәенов. **Күңел каралу** — тәрбиясезләнү, культурасызлану. *Элек заманнарда* [*алар*], *туры юлдан чыгып, күңелләре каралып, ата-бабаларына ияреп, тәмам хайван булып җиткән вакытларында, араларыннан берсе туры юлны табып, аларны туры юлга өндәмештер.* З. Һади. **Күңел килү** — кем яки нәрсә дә булса берәр кешегә ошау.— *Тагын әйт аңа: күп уйламасын, Күңле килгәнгә кияүгә барсын.* Җыр. **Күңел китек (сынык) булу** — нинди дә булса бер яктан канәгатьсезлек, ризасызлык хисе булу. **Күңел китеклеге** — нинди дә булса берәр канәгатьсезлек; тормышта берәр яктан кимчелек булу турында. [*Искәндәр:*] *Бала өчен иң аяныч күңел китеклеген — аның ятим, үги икәнен яшереп, үз балаларыгыз белән бер күреп тәрбияләгәнсез.* Г. Гобәй. **Күңел китү** —1) *к.* күңел кырылу; 2) *к.* күңел төшү. [*Габдулла:*] *Нәрсә син ул хәтле тирән уйга чумып киттең? Корбангали агайның оҗмахтагы хур кызларына күңелең киттеме әллә?* Ш. Камал. **Күңел кичереше** — эчке кичереш, хис. [*Чжу картның*] *күңел кичерешләрен чагылдырып, секунд саен үзгәрә барган, яңаклары эчкә батып кергән саргылт йөзе тимгелләнеп кызара бара.* А. Шамов. **Күңел киң булу** — кешеләргә карата ярдәмчел, игътибарлы булу. [*Шәйхел:*] *Күңел киң булса, урын тарлыгыннан курыкмыйм мин.* Г. Ибраһимов. **Күңел киңәю** *диал.*— *к.* күңел булу. *Кызның күңеле киңәйде. „Нигә печән җыюдан качтың", — дип, берсе дә бәйләнмәгәч, яңадан барып җыярга өметләнде. Абзасына да, әнисенә дә, яшь җиңгәсенә дә, башкаларның һәммәсенә дә эре-эре җиләкләр, тамарга торгандай салынган тәлгәшләр өләште.* Г. Ибраһимов. **Күңел котырыгы** — азгын хис, начар хис. *Ялкаулык илә күңел котырыгы артыннан йөрмәк адәм угылын авыру итәр.* Шура. **Күңел кошы** — кемнең дә булса яраткан кешесе, сөеклесе. *Күңел кошым миңа хат язганда Күзен йомып уйга таладыр.* Ф. Кәрим. **Күңел кузгалу** — әсәрләнү, тәэсирләнү. *Яшь чагымда мин авыру дәрәҗәдә хыялый --- бер кеше идем: юк кына нәрсәләрдән тәэсирләнәм, күңелем кузгала иде.* Ш. Камал. **Күңел курку (куркыну)** — курку, шүрләү турында. [*Мәрфуга:*] *Әллә нигә күңелем куркып тора. Бүген ямьсез төшләр дә күреп бетерөем шунда.* А. Алиш. *Бакчадагы карт агачлар да әллә нинди шомлы тавыш белән караңгы төндә шауларга тотыналар. Күңел куркына, эч нидәндер шикләнә.* Г. Ибраһимов. **Күңел кызыгу** — теләү, теләк булу;

кызыксыну булу. [*Илнең*] *һәр почмагын аерым-аерым Күрер өчен күңел кызыга.* М. Гафури. **Күңел кыйналу** — газаплану, борчылу. [*Гафиятулла:*] *Кеше аркылы ишеткән сүзгә күңел кыйнала. Колактан кергән салкын сүз йөрәккә барып җиткәнче боз була.* Г. Әпсәләмов. **Күңел кыллары** *шигъ.*—кешенең эчке дөньясы, хисләре. [*Зиннәт:*] *Шунда сизәм, кешенең иң нечкә күңел кылларын чиертә торган тылсымлы моңнар каядыр читтә, уйналмый калалар.* Г. Бәширов. **Күңел кымыржу** — борчылу, борчылу хисе уяну. *Малайның күңеле кымырҗып ала: „Әби, ярманы азрак салдың түгелме!“* И. Гази. **Күңел кырылу** — *к.* кәеф китү (бозылу, кырылу). *Юк күңел кырылыр дигән уй, ул җәһәттән мин имин.* М. Гафури. **Күңел кытыклану** — әсәрләнү, берәр эш-хәрәкәтне тизрәк башкарасы килү, берәр нәрсәне тизрәк беләсе килү. *Нәрсәгә чакырылуларының сәбәпләрен Фәтхи белгәнлекне чамалагач, [Һидиятнең] күңеле кытыкланып китте.* Ш. Камал. **Күңел көзгесе** — 1) хәтер, зиһен. *Монда язылган нәрсәләр хыял һәм фаразлардан ерак булып, --- баштан үткән вакыйгаларның, күңел көзгесендә калган сурәтләрнең нәкъ үзләреннән гыйбарәт икәнен әйтеп китүне артык булмас дип уйлыйм.* М. Гафури; 2) берәр төрле күренешләрне, процессларны һ. б. чагылдыра торган нәрсә турында. *Күз — күңел көзгесе.* Әйтем. **Күңел күге** *шигъ.* — кешенең эчке дөньясы, рухи дөньясы. *Икенче көнне иртә белән уянганда Хәлимнең күңел күгендә бер болыт та калмаган иде инде.* И. Гази. **Күңел күзе** — тирә-юньне күреп белү, аңлау сәләте. *Күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге.* Мәкаль. [*Әгъзам:*] *Син алай маңгай күзең белән генә түгел, күңел күзең белән дә күрергә өйрән, карчыгым.* Р. Ишморат. **Күңел күтәрелү (күтәрелеп китү)** — яхшы кәеф барлыкка килү; шатлану. *Улларыннан тагын бер-ике рәт акча килгәч, карт белән карчыкның күңелләре бөтенләй күтәрелде.* Һ. Такташ. *Күңелләр күтәрелеп китте, тәнгә дә җылы керде. Шатлыктан җырлый-җырлый, сызгыра-сызгыра, урам буйлап тагын бик озак йөрдек.* А. Шамов. *Аның һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән күңел күтәрелә, көләсе килә иде.* М. Әмир. **Күңел күтәрмәү (күтәрә алмау)** — риза булмау; каршы килү, канәгать булмау. *Шәһәргә килгәч, берәр тәмле нәрсә ашамый китүне күңел күтәрә алмады.* М. Гафури. **Күңел почмагы** — *к.* күңел (2 мәгъ.). *Саклый алмам күңелем почмагында Әч серләремне дә, түзмәмен, Сөйләрмен мин.* Ф. Бурнаш. **Күңел (пошу) пошыну** — борчылу, кайгыру турында. *Күңел пошына, ашкына һәм гаҗәп тынычсызлана.* Ф. Әмирхан. **Күңел рәнҗү** — канәгатьсезлек хисе уяну, үпкәләү. *Рәгыя җиңгәсенә дә, кылый күз картка да аның күңеле рәнҗеде.* Г. Ибраһимов. **Күңел рәхәтләну** — канәгатьлек хисе уяну; яхшы хисләр туу. *Аның күңеле бик рәхәтләнеп китте: --- мәктәп белән бергә бөтен авыл аңар караган, аны көтә, кирәксенәләр, бик кирәк, бик мөкатдәс нәрсә — яктылык, нур сорыйлар.* Ш. Камал. **Күңел сафлану** — начар уй-хисләр юкка чыгу. [*Нәфисә:*] *Ничектер, күңелем тагын да сафланган, уйларым тагын да кыюлана төшкән кебек.* Г. Бәширов. **Күңел суыну** — 1) бизү, тәмам тую. *Хәлфәсе бай угылын, укудан һәм мәдрәсәдән бөтенләй күңеле суынмасын дип, ормыйдыр-сукмыйдыр һәм укуга бик басып кушмыйдыр.* Ш. Мөхәммәдев; 2) яратмый башлау, сөйми башлау. *Аннары Рәүфәдән аның үзенең дә күңеле суынган иде инде.* А. Шамов. **Күңел сызу (сызлау), күңел сыкрау (сыкрану)** — борчылу, бик авыр кичерү, кайгыру. [*Атының*] *мичкә кыршавы шикелле кабыргаларын күреп җаны көя, күңеле сыза, тик яхшы ат алырга кулыннан гына килми.* И. Гази. *Һәрвакыт әрни йөрәк, сызлый күңел.* М. Гафури. *Ачынып, әрнеп күңел сыкрады. Тагын... Урамнарны Көнчыгышта эшче каны белән юганнар.* М. Җәлил. **Күңел сыну** — нәрсәдән дә булса авыр хис калу; хәтер калу, үпкәләү. *Тарлыклардан күптән! күптән! Күңелем сынган.* Г. Тукай. *Әгәр менә хәзер үк Сәйфуллә килеп кермәсә, бик кадерле бернәрсәсен югалтыр, гомергә күңеле сыныр калыр төсле тоелды аңа.* Ә. Еники. **Күңел сүрелү** — нинди дә булса теләк юкка чыгу; дәрт бетү, дәрт сүрелү. [*Без сатып алырга теләгән ат*] *Зәйнагыттинне чут-чут кенә чөеп төшермәде. --- Шуны күргәч, Зәйнагыттиннең бөтенләй күңеле сүрелде.* М. Гали. **Күңел талпыну** — нәрсәгә дә булса омтылу. *Яна йөрәк... Күңел талпына.* М. Җәлил. **Күңел тарту** — теләк булу, теләү. *— Күңел тарта торган эшкә батырлык җитә ул.* Ш. Камал. **Күңел тарыгу** — авырсыну, уңайсызлану; эч пошу. [*Нәфисә*], *бу басынкы тынлыкка күңеле тарыгып: „Әнкәй, син өйдәме?“ — диде.* Г. Бәширов. **Күңел ташу (тулу)** — 1) хисләргә бик нык бирелеп китеп елыйсы килү, елау. *Аның бу сүзләре шундый ялкынлы булып чыктылар, күпләрнең күңелләре тулды, күзләренә яшь килде.* Г. Ибраһимов; 2) бик нык тәэсирләнү, әсәрләнү, дулкынлану. *Аның күңеле горурлык һәм шатлык белән ташыды.* Г. Әпсәләмов. **Күңел теләү** — *к.* күңелгә ошау. [*Шәмсекамәр:*] *19 яшемә җитеп --- берәүне дә сөйгәнем, сөя алганым юк, --- күңел теләгән кеше очрар микән?* А. Әхмәт. **Күңел туну** — хисләр бетү, дәрт бетү. [*Аклимә:*] *Әллә инде син мине Сөймисеңме? --- Әллә күңлең мәңгегә Туңдымы?* Һ. Такташ. **Күңел тынычсызлану** — борчылу, борчылу хисе кичерү. *Хәзер Вахитнең күңеле тынычсызлана, йөрәге тибә, үзен бик авыр, куркыныч җирдә торган кебек уңайсыз хис итә иде.* М. Гафури. **Күңел төпкелендә** — *к.* күңел түрендә (төбендә). *Шуңы зур эшне башлаган кешенең аның авторитетына бик кинәт китереп сугуы күңел төпкелендә берәүгә дә әйтми торган яра да калдырган иде.* Г. Ахунов. **Күңел төшү** — 1) күңелгә ошау; ярата башлау, берәр кешегә карата якынлык хисе барлыкка килү. *Күзем төшсә, күңелем төшми Син җаныйдан бүтәнгә.* Җыр. [*Байтирәк:*] *Аларның күңеле теге кызларга төшкән, сезгә хыянәт итәргә телиләр.* Т. Гыйззәт; 2) нәрсәне дә булса теләү. [*Сәхип карчык күчтәнәчне*], *үзенең сандыгының төбенә үк салып биклән, күңеле төшкән саен әзләп-әзләп кыш буе капкалап тота.* М. Гали; 3) өметсезлеккә бирелү, өметсезләнү. *Күңел төшеррлек бик күп авырлыклар күргә карамастан.* [*Җәүдәттән*] *тора-бара --- көр күңелле, тере бер кеше калкып чыкты.* Г. Бәширов; 4) кәеф бозылу, кәеф китү, кәеф кырылу. [*Җәмилә:*] *Туктa, баланың күңеле төшмәсен, туктa, баланың кәефе кырылмасын дип, атасына белгертмичә, акчалар бирәдер идем.* Г. Камал. *Көн дә болытлырак булса, бөтенләй күңеле төшеп, сөйләшми үк башлый.* И. Гази. **Күңел түгелү** — *к.* күңел ташу (тулу). *Җәгъфәрнең күңеле түгелергә генә тора иде.* Г. Галиев. **Күңел түзмәү (чыдамау)** — 1) үз-үзеңне кулга ала алмау, үзеңнең хисләреңә ия була алмау. *Кызганмыйча күңлем чыдый алмый, Бигрәк моңлы карый күзләрең.* Г. Тукай. *Бу минутларда тегелә дә күңел түзмәде, Мөнирәнең кулына кайнар яше тамып төште.* Г. Минский; 2) нәрсәгә дә булса бик нык омтылу, ашкыну. *Хәлдән таеп егылсак та алҗып, Күңел түзми, йөрәк ашкына.* Ш. Маннур. **Күңел түрендә (төбендә)** — сер итеп саклана торган уй-фикердә; гомумән уйда-хисләрдә. [*Камалов:*] *Без сине өч ел буенча күңелебезнең түрендә сакладык.* А. Шамов. **Күңел**

түреннән — йөрәгеннән, күңеленнән. *Бу кызны ул күңел түреннән чыгарып ташлый алмас. Дәүләтшинның бәхетсезлегенә каршы, бу кыз аның йөрәк итенә ябышып үскән.* И. Гази. **Күңел (үз) урынында түгел** — нәрсә турында да булса уйлану, көчле борчылу, тынычлыкны югалту турында. *Малайга нидидер зур уй төшкән, малайның күңеле урынында түгел.* Г. Бәширов. **Күңел утыру** — нәрсәне дә булса үз итү, ошату. [*Фәтхеттин:*] *Хатынның авылга күңеле утырмый, авыл эшенә кулы ябышмый, һаман каланы тарта.* М. Гали. **Күңел үз урынына утыру** — *к.* күңел басылу (тынычлану). **Күңел хушлану** — канәгатьлек хисе барлыкка килү, канәгатьләнү. *Җимерек урыннарның төзәлгәнен Күрсә, аның күңеле хушлана.* М. Гафури. **Күңел шатлану (сөену)** — әтчән шатлану, сөену. *Шуны күреп эшчеләрнең, Директорның күңеле сөенде.* М. Җәлил. *Ләкин үзе алданса да, күңеле шатланды.* Г. Әпсәләмов. **Күңел шатлыгы** — шатлык хисе. *Була шундый халәтләр, кайвакыт берәүне чын күңелдән сөясең, --- аның белән мөнәсәбәтеңне кемгә дә булса сөйләү сиңа күңел шатлыгы, җан рәхәте бирә.* Г. Ибраһимов. **Күңел шикләнү** — шикләнү хисе кичерү, шикләну. [*Рәүфә:*] *Сафа абый, никтер, күңелем шикләнә минем. --- Бу йөрү безнең яхшы булып бетмәс кебек.* А. Шамов. **Күңел эрү** — кызгану, жәлләү хисе уяну; берәр кешегә яки берәр нәрсәгә карата уңай караш туу. *Күңелем дә эри. Әллә нинди яхшы сүз әйтәсем килә.* Ф. Хөсни. **Күңел эченнән** — күңеленнән; *к.* күңел (6 мәгъ). [*Җиһанша*] *күңел эченнән тирән бер хак белән мактана.* Г. Ибраһимов. **Күңел юану** — кайгы-сагышлар онытылу, борчылулар бетү. **Күңел юксыну** — зарыгып теләү. [*Гаяз:*] *Шулай да нәрсәдер җитми иде, шулай да күңел нәрсәнедер юксына иде.* М. Әмир. *Үзем синнән башка Тора алмыйм — күңел юксына.* З. Мансур. **Күңел якын итү** — ошату, ярату; *к.* күңелгә ошау. **Күңел ярасы (җәрәхәте)** — нинди дә булса авыр хәлдән һ. б. ш. калган яки барлыкка килгән кайгы, сагыш, хәсрәт, ачыну хисе. [*Закиров:*] *Мин сезгә үземнең хәсрәтемне, йөрәгемдәге әрнүемне сөйләргә телим. Күңелемнең ярасын ачып бирмәкче булам.* А. Шамов. **Күңел ярасына тоз сибү** — берәр күңелсезлек вакытында аңлы рәвештә кешене ярсыту, борчу. *Шулай көйләнер төсле тоелганда, озын телләр, кайсы көнләп, кайберләре үч итеп, карчыкның күңеле ярасына тагын тоз сибә башладылар.* Г. Бәширов. **Күңел ярсу** — бик нык әсәрләнү, кызу, ярсу. [*Халикъ:*] *Әллә нәрсә булмады булуын, Ишмөхәммәт, әмма ләкин бик күңел ярсып китте.* Ш. Камал. **Күңел яту** *(күбрәк юклык формасында кулланыла)* — ошату, ярату, теләү. [*Карлыгач:*] *Ай ярымнан туй кылып, мине озатырга телиләр... Мәгәр күңелем ятмый.* Г. Ибраһимов. **Күңел әрнү** — *к.* йөрәк әрнү. [*Абый:*] *Әгәр бу сугыш булмаса, озакламый туй ясап, бергә --- көн итә башлар идегез. Менә шуларны уйлап күңелем әрни шул.* Ә. Айдар. **Күңел өзгеч** — авыр кичерешләр тудыра торган. *Ах, матур соң ул кояшның күңлем өзгеч моң чагы: Ул оялчан кыз йөзедәй бер кызыл ут-нур шары.* Н. Исәнбәт. **Күңел өчен** — кешене тынычландыру өчен, кемнең дә булса кәефен җибәрмәс өчен. *Картның күңеле өчен бакчаны кереп карадылар.* Г. Ибраһимов. **Күңел өшеткеч** — авыр тәэсир итә торган. [*Шәрәфи картның*] *яланғач аяк үкчәләре арттан әллә нишләп бик килешсез һәм дә күңел өшеткеч булып күренә иделәр.* Ш. Камал. **Күңел үсү (үсеп китү)** — *к.* күңел күтәрелү (күтәрелеп китү). *Эш алга барган саен, [Мидхәтнең] күңеле үсте. Аңарда яңа фикерләр туды.* Г. Гобәй — *Сезнең бу хатны җыелышта укыгач, халыкның күңеле үсеп китте.* Ә. Айдар. **Күңел җилкенү** — нинди дә булса теләк уяну, теләк барлыкка килү. *Бер сүзем юк, Дулый матур, --- Зәңгәр дулкыннарын күреп, җилкенеп куя күңел.* Ә. Ерикәй. **Күңел җитү** — 1) кирәк дип табу, тиеш дип табу. *Үзең, --- аз булса да, күңелең җиткәнчә, ярдәм кылырсың.* Ш. Мөхәммәдев; 2) ышану. *Бу атның мендерүләренә күңелем җитми.* Г. Ибраһимов. **Күңел җиңеләю** — эчке борчылулар бетү, тынычланып калу. *Әнисенә дөресен сөйләп биргәннән соң, Фәритнең күңеле җиңелләп, тынычланып, рәхәтләнеп китте.* А. Шамов. **Күңел җылыну** — *к.* күңелгә җылы керү. *Безнең күңелләр тиз үк җылынып китте.* Ш. Камал. **Күңел җылысы** — яхшы хис, яхшы караш. [*Хат*] *кырык кул аша үтеп, таушалып, буялып, укылып беткән булса да, өйдәгеләрнең күңел җылысын түкми-чәчми китереп җиткергән иде.* И. Гази. **Күңелгә авыр алу** *(күбрәк юклык формасында кулланыла)* — нинди дә булса хәбәрдән яки сүздән рәнҗү, аны бик авыр кабул итү. *Чуар тавыкны тавык димәсәң, Җамал әбинең хәтере калып, бу сүзне улы Гата да күңеленә авыр алыр.* А. Алиш. — *Эшегез болай барса, күңелегезгә авыр алмагыз, сезнең хәлләр шәптән түгел.* Г. Бәширов. **Күңелгә авыр булу** — борчылырга, газапланырга туры килү турында. [*Хәдичә:*] *Шул кеше озату кебек кыен нәрсә юк. Бигрәк күңелгә авыр була.* М. Гафури. **Күңелгә авыр тоелу** — канәгатьсезлек тудыру, күңелне борчу; ошамау. [*Хажи:*] *Тик әнә кәләпүш кимәгәнсең, әнем. Дә инде ул эшең күңелгә авыррак тоела шул.* Ш. Камал. **Күңелгә вәсвәсә (коткы) салу** — вәсвәсәләндерү, котырту.]*Хәнифә:*] *Нәрсә күңелгә вәсвәсә салып йөри соң бу.* Р. Ишморат. **Күңелгә (кереп) утыру** — оныта алмаслык булып истә калу. *Үзенең чая гомерен, таудан ага торган шарлавык төсле, тиз һәм шаулап уздырган бу йөрәкле егет минем күңелгә дә әнә шулай нык булып утырып калды.* Ф. Хөсни. **Күңелгә керү** — игътибарны, зиһенне биләү. *Урядник сизәр дигән куркыныч һәммәсенең күңеленә керде.* Г. Ибраһимов. **Күңелгә килү** — искә төшү, хәтергә төшү. [*Әманәт*] *өзлексез Мәдинәнең күңеленә килеп тора, йөрәген кимерә, ачы рәвештә эчен пошыра.* Ш. Камал. *Карты белән сөйләшкәндә, эшнең менә бу яклары да аның күңеленә килә торды.* Г. Ибраһимов. **Күңелгә китерү** — уйга китерү, уйлау, уйлап карау. *Ләкин шушы өченчә айдан бирле үзе тора торган йорттагы коңгырт чәчле, каралҗым уйчан күзле кызчыкның язмышы Фатыйманың язмышы белән бертөсле үк булырга мөмкин икәнлеген һич тә күңеленә китергәне юк иде.* Ш. Камал. **Күңелгә курку керү (төшү)** — курку, курку хисе барлыкка килү. *Җиңгидән бу сүзләрне ишеткәч, минем күңелгә курку төште.* М. Гали. **Күңелгә кәгъбә булу** — ярату, сөю хисе уяту. [*Шаһтимер:*] *Ил балалары күңеленә кәгъбә булган данлы кыз шундый хөрмәтсезлекләр күрәме?* М. Фәйзи. **Күңелгә кәгъбә итү** — ярату, сөю. [*Мавия:*] *Ул сине шунда тәү мәртәбә күрде. Һәм шул көннән алып күңеленә кәгъбә итте.* М. Фәйзи. **Күңелгә ошау** — 1) яхшы тәэсир калдыру. [*Старшина:*] *Син полковник күңеленә ошап калгансың, ул үзенә сине ездовой итеп алмакчы була.* Ә. Айдар; 2) кемнең дә булса зәвыгына, уй-теләкләренә туры килү. — [*Фазылның*] *бу эше күңелемә бер дә, бер дә ошамады.* Г. Ибраһимов. **Күңелгә салу** — 1) истә калдыру, хәтергә алу. *Рәүфә ана карчыкның йөрәгеннән чыккан сүзләрен күңеленә сала, аны тыныч ландыра.* А. Шамов; 2) искә төшерү, хәтергә төшерү. — *Шул вакыт, ходай күңелемә салгандыр инде, баягы нәрсә йөрәгенә тимәдеме икән дип, авызына сөт салырга уйладым.* Г. Ибраһимов. **Күңелгә**

таракан керү — шикләнү, шомлану турында. *Өйләренә таралышып, һәр кеше үзенең уе белән икәү генә калгач, күңелләргә тагын таракан керде: төнлә белән авылга ут салмагайлары.* И. Гази. **Күңелгә таш булу, күңелгә таш булып төшү** — *к.* күңелгә авыр алу. *Әнкәсенең сүзләре Хәлимнең күңеленә таш булып төште.* И. Гази. **Күңелгә ут салу (ягу)** — 1) борчу тудыру, уйланырга мәҗбүр итү. *Бу сүзләр электән икеләнеп йөргән солдатларның күңелләренә дә ут салды.* М. Гафури; 2) мәхәббәт хисе уяту, гашыйк итү. *Инде суындым дигәндә генә тагын күңеленә ут салмакчымы бу кыз?* И. Гази. **Күңелгә утырту** — *к.* күңел беркетү, күңелгә беркетү. [*Гыйлажи*] *баштан ук күңеленә утыртып куйды.* Г. Ибраһимов. **Күңелгә шик (шом, шөбһә) килү (төшү)** — шикләнү, шомлану, шөбһәләнү. *Күңелгә шом килә: гүя, менә-менә тагы бер-ике тапкыр* [*дулкыннар*] *ыргып атылачаклар да дөньяны каплап китәчәкләр.* Г. Ибраһимов. **Күңелгә шик (шом, шөбһә) салу** — шомландыру, шикләндерү. [*Данилов:*] *Нигә егетнең күңеленә шик саласыз?!* Г. Бәширов. **Күңелгә юаныч бирү** — *к.* күңелне юату. [*Хатның*] *һәр юлыннан, һәр сүзеннән күңелгә юаныч бирә торган, шатлык урнаштыра торган мәгънә чыгардылар.* А. Шамов. **Күңелгә якын (булу)** — нинди дә булса берәр ошаган, үз булып торган нәрсә турында. [*Ул*] *--- боларның һәммәсен күңеленә якын булган бер яңа хәят вә аның сәгадәте өчен бер дә авырсынмый сөенәсөенә эшләргә хәзер тора иде.* Ш. Камал. *Күңелемә, әйе, якын минем дә шундый солдат җырчылар.* З. Мансур. **Күңелгә ярып салу** — бик төшендереп сөйләү. *Әле җыелышта* [*Газизнең*] *сөйләгән сүзләрен ишетеп хәйран калып утырдым... Килештереп сөйли. Күңелгә ярып сала.* М. Гафури. **Күңелгә яту (ярау)** — ошау, уй-теләкләргә туры килү. *Күңелгә ятарлык бер генә җылы сүз дә юк.* И. Гази. *Д кояш исенә төшсә генә бер карый, анысы да күңелгә ярый.* А. Алиш. **Күңелгә ятышлы (ятымлы)** — ошаган, күңелдә яхшы тәэсир калдырган берәр кеше яки нәрсә турында. *Әле монда көй үзе юк, әмма тын йорт эчендә моңаеп кына сузылган бу беркатлы гади авазда ниндидер бер өмет чаткысы сизелеп китә, ул инде күңелгә ятышлы бер якты моң вәгъдә итә.* Г. Бәширов. [*Имәли:*] *Авылыбызга чибәр-чибәр егетләр килә, беренче очраганда күңелгә ятымлы гына булалар.* М. Әмир. **Күңелгә җылы керү** — шикләнү яки борчылу хисләре юкка чыгу. *Егетнең күңеленә җылы керде. Мәрхәбәнең җавабын: „Мин каршы түгел, үзең теләсәң ни эшлә", — дип аңлады.* Г. Ибраһимов. **Күңелдә бәйрәм булу** — шатлыклы хис барлыкка килү, шатлану. *Тимеренең күңелендә бәйрәм иде. Нәфисәнең картлар ягына салам кыстыруын ишеткәч, --- мыек астыннан көлеп утырды.* Г. Бәширов. **Күңелдә калдыру** — истә калдыру, хәтердә калдыру. *Аның асарга алган үксез бала икәнлеген белгәч тә, Мохтар аны-моны уйламаган, картның яисә карчыкның якыннарыннан берәр фәкыйрь кешенең баласыдыр дип күңелендә калдырган иде.* Ш. Камал. **Күңелдә йөртү (саклау)** — нинди дә булса бер хис кичерү; берәр нәрсәне хәтердә саклау; онытмау. *Якты хисне күңелдә саклау.* **Күңелдә төен (булып) калу** — нинди дә булса сөйләшүдән, вакыйгадан соң авыр тойгы калу, авыр хис калу. [*Сәйфетдин карт:*] *Рәнҗеп чыкма инде, күңелеңдә төен булып калмасын. Бу йортка бик күп хезмәт куйдың.* Г. Бәширов. **Күңелдә ут уйнау** — бик көчле кичерешләр кичерү, бик нык борчылу. *Бу сүз Закирне тәмам үтерә. Күңелендә ут уйнаса да, Закир тыштан бик салкын күренергә тырыша.* И. Гази. **Күңелдә шик (шөбһә, шом) тудыру** — шикләндерү, шөбһә барлыкка китерү. — *Аның сүзләре минем күңелдә шөбһә тудырдылар.* Ш. Усманов. **Күңелдән алып (кырып) ташлау** — аңлы рәвештә оныту, игътибар итми башлау. *Ләкин Нәфисә уяна гына башлаган бу яңа өметне дә күңеленнән кырып ташлады.* Г. Бәширов. **Күңелдән китмәү** — һәрвакыт истә булу, онытмау. [*Таһир:*] *Җилләр исте, шатлыгым—иркәм күңелдән китмәде.* Ф. Бурнаш. **Күңелдән ташып чыгу** — үзендә, үз эчендә генә саклый алмау, яшерә алмау (бик көчле, шатлыклы хис-тойгыларны, кичерешләрне һ. б.). [*Дәүләтшин*] *бүген чиксез бәхетле иде һәм күңеленнән ташып чыккан шатлыгын кем белән булса да уртаклашасы килде аның.* И. Гази. **Күңелдән уздыру (үткәрү, кичерү)** — 1) үткәннәрне яңабаштан берәмләп искә төшерү, хәтердә яңарту, искә алу. [*Хәдичә түти*] *һәммәсен дә, яңадан яшәп уздыргандай, дулкынланып күңеленнән кичерде.* Г. Бәширов; 2) уйлау, искә алу. *Хөснулла, өйдән чыгып капка янына барган чагында, төрле ихтималлар булуны күңеленнән үткәрде.* Ш. Камал. **Күңелдән узу (үтү, кичү)** — 1) бер-бер артлы хәтергә килү, искә төшү. *Кичә бу вакытта ничек рәхәт иде ---. Бу рәхәтлекләр һәрберсенең күңеленнән кичте.* М. Гафури; 2) тойгыларның бер-бер артлы барлыкка килүе турында. *Нәфисә күңеленнән күп төрле ялкынлы тойгылар узды.* Г. Бәширов. **Күңелдән чыгару** — оныту, истән чыгару. [*Гали*] *моннан биш ел элек булган шомлы вакыйганы күңеленнән чыгарып ыргытырга тели.* М. Гафури. **Күңелдән чыгу (югалу)** — онытылу, истән чыгу. *Шаһбаз белән Гыйлажи бервакытта да күңелемнән чыкмыйлар.* Г. Ибраһимов. **Күңеле белән дә, тәне белән дә** — бөтенләй, бөтен барлыгы белән. [*Газизов:*] *Мин аның үз-үзен тотуына, миңа күңеле белән дә, тәне белән дә хыянәт итмәвенә ышана идем.* А. Шамов. **Күңеле иркен (киң)** — кеше күңелен күрә белү, игътибарлы булу турында. [*Саимә:*] *Кәефем килде әле Гришага. Беребезне дә онытмый. Хәтере нык аның. Күңеле иркен.* К. Нәҗми. **Күңеле көр** — канәгать, шатлыклы булу турында. *Әнчек белән Озын койрыкның тамаклары тук, күңелләре көр иде.* Ак юл. **Күңеле китек (сыныk)** — кешедә берәр төрле канәгатьсезлек, ризасызлык хисе булу турында. *Аның ни өчен күңеле сыныk икәнен Рифгать белә иде инде.* М. Әмир. *Ләкин шулай да* [*Зәлифәнең*] *күңеле китек була: ата-ана иркәсеннән мәхрүм булып, апасы бәлән җизнәсе арасында бик еш була торган ниндидер пышылдашулар, аңлаешсыз көрсенүләр эчендә үсә ул.* Г. Ахунов. **Күңеле төзек** *иск.* — яхшы уйда булган, игелекле, яхшы. *Күңеле төзек адәм яхшы эшкә булышудан һич тартынмас.* Шура. **Күңелен алу (аудару)** — кемдә дә булса үзенә карата яхшы мөнәсәбәт барлыкка китерү; гашыйк итү. [*Мәрхәбә*] *үги каенананың күңелен алырга, туры үзенең киленлек, кардәшлек тойгыларын күрсәтергә ашыкты.* Г. Ибраһимов. [*Әбелхарис:*] *Тик мин ханның гына күңелен табыйм. Киткән данны кире кайтарыйм. --- Ничек аның күңелен аударыйм?* Н. Исәнбәт. **Күңеленне киң тот** — өмет ит, исәп тот. [*Илдар:*] *Күңелеңне киң тот, халык сиңа* [*эш*] *тапшырырга чамалап тора.* Г. Гобәй. **Күңелне аздыру** — бозык уй-фикерләр, хисләр тудыру. [*Ләлә:*] *Әгәр бу йөрешегез --- күңелемне аздырырга маташу булса, туры гына чыгып китүегез тиешлекне белдерәм.* М. Фәйзи. **Күңелне аулау** — гашыйк итү, үзенә карату. [*Нәгыйммә:*] *Шәмси миңа исле сабыннар җибәрткән иде, кибетче Хәйбулла улы кәнфитләр китерткән иде. Имеш, шуның белән минем күңелемне аулыйлар.* Г. Ибраһимов. [*Гөлчирә:*] *Сорама, җиңги, тасма телләре белән күңелемне аулады.* Т. Гыйззәт. **Күңелне ачу** — кә-

ефне күтәрү, кәефне ачу; кайгы-хәсрәтне тарату. *Дуслары-иптәшләре аңа яхшы киңәшләр бирделәр, уен-җыр белән күңелен ачтылар.* Г. Бәширов. *Уен-көлке белән күңелне ачарбыз.* М. Җәлил. **Күңелне ашкындыру** — *к.* күнелне дәртләндерү. *Аныкы шикелле, минем йөрәгемне кытыклый торган сын, аныкы шикелле, минем күңелемне ашкындыра торган адымнар җир йөзендә Алядан башка кемдә булырга мөмкин!* Ф. Әмирхан. **Күңелне басу** — тынычландыру, юату. [*Гали*] *ничаклы --- ижтиһат итеп караса да, күңелен баса алмады.* М. Гафури. **Күңелне биләү** — кызыксындыру, кызыксыну уяту. *Авыл Илдарның гына түгел, Маратның да күңелен биләде.* Г. Гобәй. **Күңелне бозу** — *к.* кәефне бозу (кыру, җибәрү). **Күңелне боектыру** — *к.* күнелне төшерү (төшенкеләндерү). *Шулай да аның идарәдә булмавы Нургалинең күңелен шактый боектырып җибәрде.* Ә. Еники. **Күңелне болгандыру (болгату)** — 1) косасыны китерү; 2) авыр тәэсир итү, начар тәэсир ясау. *Бу хәбәр байның күңелен бик болгатты.* Ш. Мөхәммәдев. **Күңелне борчу** — борчылу хисе тудыру, борчу, тынычсызлау. *Игеннәрнең начар үсүләре дә кешеләрнең күңелләрен шактый борчый.* Ш. Камал. **Күңелне бушату** — үз эчендәге уй-фикерләрне сөйләү. *Ораторлар, бер-бер артлы чыгып, күңелләрен бушата башладылар.* И. Гази. **Күңелне бәйләү** — кемне дә булса үзенә карату. — *Хәлил дә йокламаган: бөтен тирә-юнь егетләре күз тотып торган кызның күңелен бәйләп өлгергән.* М. Фәйзи. **Күңелне дәртләндерү** — кешедә дәрт барлыкка китерү, дәрт тудыру. *Ялкын өсти кайнар йөрәккә бу* [*медаль*], *Дәртләндерә һаман күңелне.* З. Мансур. **Күңелне иләс-миләс китерү** — *к.* күнелне кузгату (уяту). [*Солдатлар*], *мостовой ташларына гөрс-гөрс басып, кулларын киң селтәп, дәртле җыр белән кешеләрнең күңелләрен иләс-миләс китереп, Кремльгә таба узып киттеләр.* И. Гази. **Күңелне имрәтү** — *к.* күнелне йомшарту (йомшату). *Бигрәк тә җирән бияне алырга тотылган егерме биш сум турында ләм-мим дип сүз кузгатмавы Ишмайны тагын шатландырды, аның күңелен имрәтеп җибәрде.* Ш. Камал. **Күңелне йомшарту (йомшату)** — 1) дулкынландыра торган хисләрне уяту, бик нык тәэсирләндерү, дулкынландыру. *Бу хат ата белән ананың күңелен йомшартты.* Һ. Такташ. *Энесенең күчтәнәчләре бөтенләй аның күңелен йомшатып җибәрде.* Ә. Фәйзи; 2) кызгандыру, жәлләтү; берәр кешегә яки берәр нәрсәгә карата уңай караш уяту. *Бу бүләкләр белән картның рәнҗүле күңелен йомшартырга, түй арасында тавыш чыгармау җаен карарга теләде.* Г. Ибраһимов. **Күңелне кайтару** — нинди дә булса теләкне, омтылышны бетерү; кәефне җибәрү. [*Хөрмәтулла:*] *Бүген дә үзе белән сөйләшергә дип сүз башлаган идем, күңелне кайтарды.* Т. Гыйззәт. **Күңелне калдыру** — үпкәләтү, рәнҗетү, хәтер калдыру. [*Җәмилә:*] *Алай олы кешенең күңелен калдырмыйлар аны.* Г. Камал. **Күңелне канатландыру** — дәрт бирү, дәртләндерү. *Шатлык күңелне канатландыра.* **Күңелне кимерү** — борчу, уйландыру. *Тик менә заманаларның чуалып китүе генә күңелне кимереп тора.* И. Гази. **Күңелне кузгату (уяту)** — кешедә нинди дә булса теләк, уй яки хис уяту. *Инде алай да* [*Нәфисәнең*] *күңелен кузгата алмагач: „Уф“ дигәннең мәгънәсен Белми кайсы бәндәләр“, — дип тә чеметтергәли торган булдылар.* Г. Бәширов. **Күңелне куркыту** — кешедә курку хисе барлыкка китерү. *Әллә кайдан һичвәлексез ишетелеп торган мылтык тавышы, бер әкренәп, бер куәтләнеп, куркынган күңелне тагын да ныграк куркыта.* Ш. Усманов. **Күңелне кымыржыту** — беркадәр борчу, бераз уйландыру. *Һәркемнең күңелен кымыржытып торган нәрсәләрне кузгатып җибәрергә шул җитә калды.* М. Шабай. **Күңелне кыру** — *к.* күнелне бозу. — *Ул Шаһтимер гашыйкның күңелен кыруны шул йөргән куйларның аягын кырудан да җиңел санады.* М. Фәйзи. **Күңелне кытыклау (кытыкландыру)** — тәэсирләндерү, әсәрләндерү, җиңелчә ярсыту. *Фәтхи, сүзне кырт кисеп китеп баруы белән,* [*Һидиятнең*] *күңелен тагын да артыграк кытыкландырып калдырды.* Ш. Камал. **Күңелне күрү (табу)** — нинди дә булса юл белән кешенең кәефен ачу, канәгатьлек хисе уяту. *Бу тартынкылыкны күреп торган Зифа карчык, Шәрифулланың күңелен табарга тырышып, --- аның һәр хәрәкәтенә ярдәм итәргә тырыша иде.* А. Шамов. *Зур кешеләрнең күңелен күрим дигәндә Баһаветдин агай җанын да жәлләми инде: бишкә, кирәк икән, кырыкка бөгелә ала.* Н. Фәттах. **Күңелне моңландыру** — моңсу хис уяту, беркадәр сагышландыру. *Бу күренеш аның күңелен моңландыра.* Ш. Камал. **Күңелне нечкәртү** — *к.* күнелне йомшарту (йомшату). *Бөек Иделнең киң күкрәге белән озак-озак итеп тын алуы ничектер күңелне нечкәртә, таң нурыдай якты уйлар туа иде.* Г. Бәширов. **Күңелне ныгыту** — *к.* күнел беркетү, күңелгә беркетү. **Күңелне очындыру** — *к.* күнелне дәртләндерү. *Бөтен шушы чуар күренеш Гафиятнең күңелен тагын очындырып җибәрде: „Бөтен ил белән кузгалдык, хәерле сәгатьтә булсын!“ — дип уйлады ул.* И. Гази. **Күңелне рәнҗетү** — үпкәләтү, рәнҗү хисе уяту; хәтер калдыру. *Яшь бай дхминең бу көнге бер катылыгы картның күңелен бигрәк нык рәнҗеткән.* Г. Ибраһимов. **Күңелне рәхәтләндерү** — канәгатьлек хисе уяту, яхшы тәэсир итү. *Дымлы кара туфрак, күңелне рәхәтләндереп, тәмле ис аңкытып, актарыла башлады.* И. Гази. **Күңелне саклау** — *к.* хәтерне саклау. [*Зәйнәп:*] *Ашасаң, безнең өйдә сүз әйтүче юк та, анакайның күңелен саклап, без инде ашамыйбыз.* Ф. Әмирхан. **Күңелне сафландыру (сафлау, пакьләндерү)** — начар уй-хисләрне бетерү, юкка чыгару; әхлакый яктан сафландыру. *Дуслык — кешенең күңелен сафландыра, димәк, ул кешенең барлык башка хисләрен нәфисли.* Г. Әпсәләмов. *Тап вә кердән, пычранудан бу күңелне сафлый ул* [*вөҗдан*]. М. Гафури. **Күңелне сихәтләндерү** — кайгылы, борчулы уй-хисләрне бетерү, юкка чыгару; рәхәтлек бирү. [*Газизнең киемнәрен*] *сыйпаштыру гына да ана кешенең сагыну һәм юксынудан яраланып беткән күңелен сихәтләндереп җибәрә иде.* Г. Бәширов. **Күңелне суындыру (суыту)** — бизү, яратмый башлау. [*Закир:*] *Бу нинди ир тавышы, әллә юк исә чыннан Гайни миннән күңелен суытканмы?* Г. Камал. **Күңелне сызлату (сыкрату)** — борчу, тынычсызлау; сагышландыру, кайгылы хисләр уяту. [*Локман:*] *Уф, эшсез ятуны нинди газап! Эч пошу йөрәкне тырный, күңелне сызлата.* Ш. Камал. **Күңелне сыкрату** — күңелсез, кайгылы хисләр уяту; борчылдыру, борчылу хисе уяту. *Моның нәтиҗәсендә матур тәмле хыял һәм өметләр һәрвакыт җимерелеп, алар урынын эчпошыргыч, күңелне сыкраткыч, омтылышларны буучан чынбарлык ала.* Г. Нигъмәти. **Күңелне сындыру** — үпкәләтү, рәнҗетү; хәтерен калдыру. [*Байтурә:*] *Картны рәнҗеткән, күңелен сындырган чагым аз* [*булмады*]. Г. Ибраһимов. **Күңелне тарту (җәлеп итү)** — үзенә карата кызыксыну уяту, кызыксындыру, игътибарны җәлеп итү. *Мохтар бу малайда күңелне үзенә тартырлык һичбер хасият тапмый.* Ш. Камал. [*Ильяс:*] *Самат та авыл балалары эчендә иң яраткан бер егетем. Класста укыган чагында ук күңелемне җәлеп иткән ул малайга бәхетләр теләүче дус мин.* М. Фәйзи. **Күңелне ташыту** — әсәрләндерү, тәэсирләндерү;

елату, еларга мәҗбүр итү. *Бер үк вакытта Гөлгенә бу сүзләре белән Хәлимнең тулган күңелен ташытты.* Г. Гобәй. **Күңелне телү** — бик нык борчу. *Ник төшердең күзләреңә? Ник минем күңлемне телдең?* Н. Исәнбәт. **Күңелне тетрәту** — хисләргә бик нык тәэсир итү; бик нык дулкынландыру. *Бала күңелен тетрәткән бу фажигането ярасы әкренләп төзәлә барды.* Г. Бәширов. **Күңелне тибрәту** *шигъ.* — дулкынландыру; хисләр уяту. *Бу сүзләр солдатларның күңелләрен шундый бер гажәп көч белән тибрәтеп җибәрделәр.* К. Нәҗми. **Күңелне тутыру** — 1) бик нык тәэсирләндерү, дулкынландыру; елыйсыны китерү. *Аның күзләрендә елтырый башлаган яшьләре минем дә күңелемне тутырдылар, бугазыма яшь тыгылды.* Ф. Әмирхан; 2) нинди дә булса хис-тойгы уяну турында. *Яткач та бик арыган кешенең йомшак һәм уңайлы урынга сузылганда хис итә торган бер рәхәтлек тойгысы аның күңелен тутырды.* Ш. Камал. **Күңелне тынычландыру** — эчке борчулуларны юкка чыгару. [*Гарәфи:*] *Күңелне тынычландырыр өчен чыгып утырдым әле.* Г. Әпсәләмов. **Күңелне тырнау** — борчылу хисе уяту, борчу. — *Бөтен кайгы-хәсрәтне онытып, күңелне тырнап торган кайгыны онытып, ашыйсы килүне онытып, көн буе менә шулай барасы да барасы иде.* И. Гази. **Күңелне төшерү (төшенкеләндерү)** — өметсезләндерү, өметсезлеккә төшерү; моңсуландыру. *Йөзендәге сипкелләре вакыт-вакыт аның күңелен төшергәләсәләр дә, вакыт-вакыт ул бу сипкелләр сәбәбеннән үземә егетләр карата алмамдыр дигән өметсезлеккә чумып көенсә дә, болар аңардан тиз үтәләр иде.* Г. Ибраһимов. **Күңелне утырту** — карар итү, берәр нәрсәне максат итеп күю. *Вәли үзенең шагыйрь булачагына күңелен утыртты да бөтен буш вакытын шигырь язарга сарыф итә башлады.* Ан. **Күңелне эретү** — кызгану, жәлләү хисе уяту; берәр кешегә яки берәр нәрсәгә карата уңай караш тудыру. *Кыз да елмайды һәм күңелне эретеп җибәрерлек йомшак тавыш белән: „Гвардеец, даруны эчеп җибәрегез...“ — диде.* А. Әхмәт. **Күңелне юату** — нинди дә булса юл белән кайгы-сагышларны тарату, авыр кичерешләрне, уйларны онытыру. *Һәм иркәләп җылы сүзләр белән Ул Алсуның күңелен юатты.* М. Җәлил. *Ләкин ул туп-туры гына чыгып китмәде, кайсыңдыр урынҗирен уңайлады, кемгәдер су бирде һәм күңелләрен юатырлык җылы сүзләр әйтте.* А. Шамов. **Күңелне ярсыту** — 1) кешедә нинди дә булса хисләр, теләк яки омтылыш уяту. *Бик күпләрнең күңелләрен ярсыткан ул, Биегәндә бәйрәмнәрнең күрке булып, Егетләрнең иң шәпләрен алҗыткан ул.* Ф. Бурнаш; 2) борчылдыру, борчылу хисе уяту. [*Садыйк:*] *Янымда синең булмавың гына күңелне ярсыта.* Г. Ибраһимов. **Күңелне әрнетү** — ачындыру, канәгатьсезлек уяту, авыр хисләр барлыкка китерү; бик авыр тәэсир итү. *Соңгы ике-өч айда Якубның җанын талап, күңелен әрнетеп торган уйлары, тойгылары кинәт ташыды чыкты.* И. Гази. **Күңелне үстерү** — дәрт бирү, дәртләндерү; рухландыру. *Ул ялкын кешене яшәртә, күңелне үстерә, эшкә, хезмәткә дәртләндерә.* Г. Минский. **Күңелне җилкендерү (җилкетү)** — 1) дәртләндерү, дәрт бирү; дәрт өстәү. *Төрле тавышлары белән тирә-якны яңгыратып торган кошлар күңелне җилкендереп, әллә кая, читкә китәргә кызыктыра башладылар.* М. Гафури; 2) хисләр уяту, хисләр тудыру. *Кояшның беренче нурлары белән һавага күтәрелгән сабан тургаеның чишмә суыдай челтерәп аккан җыры күңелләрне җилкетә.* И. Гази. **Күңелнең иң нечкә кыллары** *шигъ.* — иң тирән хисләр турында. *Нәфисәнең дәртле җыры, яшь мәхәббәтнең иркә һәм тирән тойгыларыдай, күңелләрнең иң нечкә кылларын чиертә-чиертә, зал эчендә тибрәнә башлады.* Г. Бәширов. **Күңелнең кәгъбәсе** — 1) кемне дә булса үзенә караткан кеше; кемнең дә булса мәхәббәте төшкән кеше. [*Мавия:*] *Син кызлар күңеленең кәгъбәсе икәнеңне белмисең. Син сөймәсәң дә, кызлар сине сөя.* М. Фәйзи; 2) кемнең дә булса уй-хисләрен тарткан нәрсә. *Башкала — күңелемнең кәгъбәсе.*

КҮҢЕЛЛЕ I *с.* **1.** Шат рухлы, шат табигатьле. [*Сәлимә:*] *Безнең әни бик күңелле карчык булып бара.* Ф. Әмирхан. *Минһаж --- күңелле кеше: ул күпне күргән карт.* М. Гафури. || Шат, көр. *Кайчандыр үзенең беркатлы, күңелле табигате белән артыкурага ямь биреп торучы --- бу акыллы кызны Нәсимә беренче күрүдән үк ошаткан иде.* К. Нәҗми.

2. Яхшы кәеф барлыкка китерә торган, шатлык тудыра торган, шатлыклы. *Ял вакытларында алар үзләре эшләгән җирдән күпме бодай чыгарга тиешлеге, күпмесен фронтка биреп, күпмесен орлыкка калдырырга кирәклеге турында күңелле әңгәмәгә кереп китә торганнар иде.* Г. Бәширов. *Бу күңелле күренешне күзәтеп торган Светлананың әтисе елмайды.* Г. Минский. || *рәв. мәгъ.* Шатлык белән, яхшы кәеф белән, кәефләнеп. *Шулай күңелле генә килгәндә, пассажирлар бар да, сүз куешкан кебек, кинәт тынып калдылар, сөйләшкән, көлешкән тавышлар берьюлы тынды.* Г. Гобәй.

3. Яхшы, яхшы тәэсир итә торган. [*Сөләйман:*] *Һәр күңелсез нәрсәнең бер күңелле ягы да була, диләр.* Ф. Әмирхан. *Минем бала чагымда якты, җылы һәм күңелле истәлекләр калдыручылар бездән ике генә йорт аркылы яшәгән әхтәм бабай белән аның карчыгы Гөләндәм әби булдылар.* Г. Гали. || *рәв. мәгъ.* Яхшы, шәп, кызыклы. *Безнең бу ай ярым гомер чынлап та күңелле үтте.* М. Гафури. *Бану узган ел Гәрәй исемле егеткә кияүгә чыккан һәм хәзер матур гына, күңелле генә яши иде.* А. Шамов. || *рәв. мәгъ.* Шактый яхшы тәэсир итеп. *Таң атып, агач башында төн үткәргән кошлар күңелле чөкердәшә башлагач кына, Закир үзенең Разиясын озатып куя.* И. Гази.

4. Шатлыклы кәефне чагылдырган, күңеллелекне белдергән. *Станция ягыннан килгән бер солдат күңелле тавыш белән кычкырып җибәрде.* Ш. Камал.

5. Кайбер сыйфатлар белән килеп, алар нинди үзлекне тәгъбир итсә, кешенең эчке дөньясы, характеры шундый дигән мәгънәне белдерә. *Саф күңелле. Киң күңелле. Йомшак күңелле. Тар күңелле.* □ [*Җәмилә:*] *Атасы никадәр каты күңелле кеше, шулай да булса* [улын] *кызгана.* Г. Камал. *Барысы да Катяның бүген аеруча шат күңелле, көләч йөзле булуына игътибар иттеләр.* Г. Әпсәләмов.

6. *хәб. функ.* Шатлык, тулы канәгатьлек, рәхәтлек хисләре кичерү турында. *Урамда нинди күңелле!* И. Гази. *Яшәү тәмле, яшәү күңелле.* М. Җәлил. || Кызык, яхшы, рәхәт. *Борылырга да урын калмаган бу кечкенә киоскта Нуруллинга күңелле, рәхәт.* А. Шамов.

КҮҢЕЛЛЕ II *и. иск.* Сугыш вакытында үз теләге белән армиягә язылып хезмәт итүче кеше; ирекле. — *Нишлиләр безнең күңеллеләр, Ни хәлдә гаскәрең?* Ф. Бурнаш. *Күңелле булып язылган милиция* [*хезмәткәрләре*] *арасында „Мөхәммәдия“ шәкертләреннән Ибраһим Килдиев, Закир Закиров --- һәм башкалар булганлыгын күрәбез.* Каз. утл.

КҮҢЕЛЛЕК *и. сөйл.* Күңел өчен билгеләнгән (куелган) нәрсә (күбрәк ашамлыклар турында). *Туемлык түгел, күңеллек.* Мәкаль.

КҮҢЕЛЛЕЛЕК *и.* **1.** Күңелле булу, шатлыклы булу; күңелгә яхшы тәэсир итү. *Һаваның сафлыгы, табигатьнең матурлыгы, дөньяның гүзәллеге, яшәүнең күңеллелеге исертте мине.* А. Шамов. [*Зифа:*]

Авыл матур. - - - Мондый күңеллелек, мондый матур тормыш авылда, авылда, бары авылда гына булырга мөмкин. М. Фәйзи.

2. Шатлыклы кәеф, күтәренке рух; шатлык. *Миңлегөлнең кайтып килүе Хәйбулланың йөрәгендә сизелер-сизелмәслек кенә күңеллелек тудырды.* Ш. Камал. *Яктылыкка баткан клуб эче, Матур җиһаз белән киенгән, Күңеллелек һәм җылылык аңкый Гөлләреннән, һәрбер җиреннән.* Ш. Маннур.

3. Уен-көлке, юаныч. *Курайлы елга буенда җиләк-җимеш җыю да печән өсте белән бервакыткарак туры килә. Бусы инде үзе бер күңеллелек.* Г. Галиев. *Бик күп уйный, наян ул; Күңеллелек, көлкеләр таба әллә каян ул.* Г. Тукай.

4. Кайбер сыйфатлар белән килеп, кешенең эчке дөньясы, характеры үзенчәлеген белдерә. [*Сестра:*] *Аның җитдилеге кайчак каты күңеллелеккә кадәр барып җитә торгандыр?* А. Шамов. *Тормышта шундый кешеләрне очратасың, алар үзләренең гажәп ачык күңеллелекләре, гадел һәм гадилекләре белән сиңдә, күрүеңә үк, әйбәт тәэсир калдыралар.* Г. Минский.

КҮҢЕЛЛЕЛӘНДЕРҮ *ф.* Яхшы кәеф барлыкка китерү, кәефләндерү, күнелне ачу. *Моның өстенә эшчеләрнең эштән бушаган вакытларында тау буена җыелып уйнаулары, гармонь тартып биюләре дә күңеллеләндерә торган иде.* М. Гафури. *Әтисенең шаярып сөйләшүе аны тагын да күңеллеләндерде.* Ш. Камал.

КҮҢЕЛЛЕЛӘНҮ *ф.* **1.** Яхшы кәеф барлыкка килү; кәефләнү; шатлану. *Гөлбану бу мактаудан күңеллеләнде, үзенә сокланып карап, көзге алдында әйләнде, күзенә, битенә елмаю чыкты.* Г. Ибраһимов. *Ул моннан соң тагын да татлырак сүзләр килеп чыгуны өмет итеп, күңеллеләнеп китте.* Г. Бәширов.

2. Ямьләнү, матурлану, күнеллегә әйләнү. *Ил сәхнәсе гөлләнде, Тормыш күңеллеләнде.* М. Фәйзи.

КҮҢЕЛЛӘНДЕРҮ *ф. сөйл. к.* күңеллеләндерү. *Вахит - - - әле әтисе, әле әнисе, әле Мәрьямгә төрле сүзләр кушып, төрле сөальләр биреп күңелләндереп йөреде.* М. Гафури.

КҮҢЕЛЛӘНҮ *ф. сөйл. к.* күнеллеләнү. *Үз хакында әйтелгән яхшы сүздән һәркем азмы-күпме күңеллә.* Г. Ибраһимов.

КҮҢЕЛСЕЗ *с.* **1.** Кайгылы, сагышлы, кәефсез (кеше турында). [*Шәмсия:*] *Улым Марат, син нигәдер күңелсез, әллә берәр җирең авыртамы?* Т. Гыйззәт. [*Ләбибә:*] *Сәлим абыйны әйтәм. Ул бүген шундый күңелсез. Мин аны кызганам.* Р. Ишморат. || Кайгы чагылдырган, сагыш белдергән. *Малай күңелсез генә кыяфәт белән борылып китте.* Ш. Камал.

2. Кайгы, хәсрәт, сагыш тудыра торган; кайгылы, сагышлы, шатлыксыз. *Зәйнәп, бу күңелсез хәлләрне күргәч, елый вә үкси башлады.* М. Гафури. *Көтмәгәндә бик күңелсез хәбәр алдым мин.* Б. Рәхмәт. || *рәв. мәгъ.* Кайгылы рәвештә, кайгылы кыяфәттә. *Җансыз күзләрен кара, җимерек идәнгә күңелсез генә текәп, бишмәтенә төренә-төренә, туңган шикелле калтыранып, дәвам итте.* А. Шамов.

КҮҢЕЛСЕЗЛЕК *и.* **1.** Күнелсез булу, кайгылы булу. *Аның күңелсезлегенең сәбәбен иптәшләре төрлесе төрлечә юрады.* Г. Әпсәләмов. || Кайгы, сагыш, хәсрәт, моңсулык. *Миндәге күңелсезлек Гаяз йөзендә дә чагылган төсле күренә иде.* М. Әмир. *Һәммәсенең йөзендә әллә нинди бер күңелсезлек, борчылу сизелә иде.* Г. Бәширов.

2. Күнелсез хәл, күнелсез вакыйга; кешегә авыр тәэсир итә торган хәл. *Сарсымбайлар өчен бу зур бер күңелсезлек булды.* Г. Ибраһимов. *Һич көтмәгәндә [Нәгыйм] зур гына күңелсезлеккә очрады.* Ш. Камал.

КҮҢЕЛСЕЗЛӘНДЕРҮ *ф.* Кәефне җибәрү, кайгыга төшерү, хәсрәтләндерү, борчу. *Хат, әлбәттә, мине бик күңелсезләндерде.* М. Гафури. *Иң яхшы укучыларыннан аерылу [укытучыны] беразга күңелсезләндерде.* А. Әхмәт.

КҮҢЕЛСЕЗЛӘНҮ *ф.* Кәеф китү, кәеф юкка чыгу; кайгыру, хәсрәтләнү; борчылу. *Айсылу баш врачның әле берәр атнасыз чыгарга киңәш итмәвен килеп әйткәч, Тимери яңадан күңелсезләнде.* Г. Бәширов. *Беркөнне эштән кайтуга, Газинур, Газзәннең койкасын буш күргәч, бик нык күңелсезләнде.* Г. Әпсәләмов.

КҮҢЕЛСЕЗЛӘҮ *ф. сөйл. к.* күңелсезләндерү. [*Мавия:*] *Хәзер килмәсен. Күзләремнең кызыллыгы аны күңелсезләр.* М. Фәйзи.

КҮҢЕЛЧӘК *и. сөйл.* Кеше күңелен күрүчән, ярдәмчел кеше. *Улың күңелчәк булса — атының бәхетсезлеге, кызың күңелчәк булса — башының бәхетсезлеге.* Мәкаль. *Иренчәк кеше — чигенчәк, илгәзәк кеше — күңелчәк.* Мәкаль.

КһЕ-КһЕ *аваз иярт.* Җиңелчә йөткерү тавышын белдерә. *Теге хатын көянтә-чиләген асып моның ихатасына аяк басуы була, бу кһе-кһе дип тотына йөткерергә.* Әкият.

Л

Л Татар алфавитында уникенче хәреф.

ЛА *кис. сөйл.* 1. Сөйләмгә фамильярлык, беркадәр тәкәллефсезлек төсмере кертеп, төп фикерне көчәйтү, шуңа басым ясау өчен кулланыла. [*Шәмсетдин:*) *Ай, тәмам сагыз булдыгыз ла соң, яшьләр, сөйлә дә сөйлә, дисез, тын алырга да бирмисез.* А. Шамов. [*Әхтәри:*] *Ярый ла, синең үз улың шәһәрдә дин бозып ята, минекеләр дөрләп янган ут эченә баралар.* Т. Гыйззәт. || Раслау яки инкяр итүне белдергән сүзләр янында килеп, шул сүзләрнең мәгънәсен көчәйтә. [*Тәзкирә:*] *Юк ла инде, --- нишләп үзебез өчен булсын, ферма өчен.* Ә. Еники. [*Шахтер:*] *Ударник ла мин.* Һ. Такташ. *Юктырсың ла алла!.. Әгәр булсаң, Сабыр итмәс идең бу эшкә.* М. Гафури.

2. Шарт фигыль формалары янында килеп, беркадәр тәкәллефсезлек, фамильярлык төсмере белән нинди дә булса теләкне, үтенечне һ. б. ш. белдерүдә катнаша.— *Әфәнделәр, зинһар, тавышланмыйча гына утырсагыз ла.* Г. Камал. [*Нәгыймә карчык:*] *Дәй, юкларны сөйләп утырмасагыз ла! Кеше чынлап сөйлилләр дип уйлар.* Ш. Камал. || Боерык фигыльләр янында килеп, үтенү, сорау, теләк мәгънәсен көчәйтә һәм беркадәр тәкәллефсезлек, фамильярлык төсмере өсти. [*Сәлимә:*] *Жалованьең үзеңә булсын ла, зинһар.* Ф. Әмирхан. [*Халисә:*] *Дәй, авызыңнан җил алсын ла!* Г. Гобәй.

3. Сөйләмдә белдерелгән шик-шөбһә мәгънәсен көчәйтә. [*Сәйфи:*] *Ярый ла, казна орлык бирсә.* Г. Бәширов. || Раслауга яки инкяр итүгә беркадәр шик-шөбһә төсмере кертә. *„Булмас ла“,— диде ышанмыйча Габдулла.* Ә. Фәйзи.

4. Җырда, бигрәк тә озын җырларда, текстны көйнең ритмикасына туры китерү өчен кулланыла. *Ай бормалы, бормалы ла Бормалы су буйлары.* Н. Исәнбәт. *Казан суы буенда ла язгы сабан туенда.* Җыр.

ЛАБАЗ *и.* 1. Ашлык, он һ. б. ш. нәрсәләрне саклый яки сата торган бина. *Ике ягы яшел түбәле келәтләр, лабазлар, складлар белән әйләндерелгән киң ишек алдына барып кергәндә, урам яктагы ике катлы биек сарайдан --- кызлар, егетләр чыгып киләләр идә.* Г. Ибраһимов. *Садыйкның йорты тәртипсез рәвештә бер-берсенә беркетелеп эшләнгән лабазлар, келәтләр һәм терлек-туар абзарлары белән тулган.* Г. Гали.

2. Берәр нәрсәне саклау яки эчендә нинди дә булса эш башкару өчен ясалган әвеслек, сарай. *Чан дигәннәре шушы бик зур лабаз эчендә уртадан юллар гына калдырып ясалган, төп һәм стеналары цементтан койган дүрт почмаклы зур гына базлардан гыйбарәт иде.* Ш. Камал.

ЛАБАЗЧЫ *и. иск.* Лабаз (1 мәгъ.) хуҗасы яки лабазда сату итүче.

ЛАБАСА *кис. сөйл. к.* ләбаса.— *Ләкин бит һәр эшнең үз вакыты, үз тәртибе бар лабаса.* И. Гази. [*Нуретдин:*] *Андый фермаларның барлыгын без ишетеп торабыз лабаса.* Ә. Еники.

ЛАБИАЛЬ *с. лингв.* Иреннәр катнашы белән әйтелә торган (авазлар турында). *Лабиаль тартыклар.*

ЛАБИАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф. лингв.* Кайбер авазларны әйткәндә иреннәрне алга таба сузып түгәрәкләү, бөрештерү, иреннәрне түгәрәкләп авазлар әйтү.

ЛАБИАЛЬЛӘШҮ *ф. лингв. к.* иренләшү.

ЛАБИРИНТ I *и.* 1. Грек мифологиясендә: бик күп бүлмәләре һәм буталчык коридорлары булган зур бина, сарай.

2. Биналар, коридорлар, галереялар, урамнар яки юлларның катлаулы, буталчык урынлашуы турында. *Урамнар лабиринты.* □ [*Парижда*] *таш баскычларда, җир асты тимер юлына төшә торган җирләрдә — лабиринтларда — сәләмәләр көтүе күренә, алар шунда йоклаганнар.* Г. Гали. [*Ризванов:*] *Син ничек мине бу лабиринтлардан эзләп таптың?* Ф. Хөсни.

ЛАБИРИНТ II *и. махс.* Умырткалы хайван һәм кешенең ишетү, тигезлек саклау хезмәтен үти торган эчке колагы.

ЛАБОРАНТ *и.* 1. Лабораториядә, гыйльми учреждениедә фәнни-техник хезмәткәр.

2. Профессорга яки укытучыга студентлар, укучылар белән лаборатор занятиеләр үткәрү өчен приборлар, препаратлар һ. б. ш. нәрсәләр әзерләп торучы кеше; профессор яки укытучы ярдәмчесе. *Профессор өчен бу яңа лаборантның [Рәхимнең] уйлануларын тыңлау шактый ләззәтле эш иде.* А. Расих.

3. Кайбер предприятиеләрдә, учреждениеләрдә нәрсәгә дә булса анализ ясау яки нәрсәне дә булса тикшерү белән шөгыльләнүче хезмәткәр. *Поликлиника лаборанты. Заготзерно лаборанты.*

ЛАБОРА'НТКА *и.* Лаборант хатын-кыз.

ЛАБОРАНТЛЫК *и.* Лаборант хезмәте, лаборант булу, лаборант вазифасы.

ЛАБОРАТОРИЯ *с.* Лабораториядә алып барылган, лабораториядә ясалган. *Лаборатор тикшеренүләр. Лаборатор анализ.*

ЛАБОРАТО'РИЯ *и.* 1. Тәжрибәләр үткәреп, фәнни-тикшеренү эше алып бара торган учреждение яки аның бүлеге; шундый учреждение яки бүлек урнашкан бина яки бүлмә. *Озакламый кәкре сары тәпиле кара Дүрткүзне лабораториягә алып керделәр.* А. Расих. [*Дәүли:*] *Җир йөзенең барлык почмакларында --- лабораторияләр оештырырга кирәк.* К. Тинчурин. || *с. мәгъ.* Шунда башкарыла торган. *Ул кичне Дәүләтшин гомерендә беренче тапкыр үзенең лабораторияә эшеп аннан-моннан гына эшли:*

ашыга, кабалана: анализларны ахырына кадәр җиткерми. И. Гази.

2. Предприятиенең, учреждениенең нәрсәгә дә булса анализ ясау яки нәрсәне дә булса тикшерү белән шөгыльләнә торган бүлеге; шул бүлек урнашкан бина яки бүлмә. *Фабриканың химия лабораториясе. Төрле приборлар. Шкаф, урындыклар.* Р. Ишморат.

3. Уку йорты яки мәктәп каршында кайбер предметларны (мәсәлән, химияне, физиканы) өйрәнүгә ярдәм итү өчен махсус оештырылган, тәҗрибәләр ясау өчен тиешле препаратлары һәм приборлары булган кабинет. *Лаборатория шартларында бакыр окисеның углерод окисе белән кайтарылуын --- приборда тәҗрибә ясап күрсәтергә мөмкин.* Химия.

4. *күч.* Иҗади эшчәнлек өлкәсе; кемнең дә булса шәхси эш процесслары, шәхси эшчәнлеге турында. *Язучының иҗат лабораториясе. Художникның иҗат лабораториясе.*

ЛАБРАДОР *и. махс.* Кыр шпатының бер төре (биналарны бизәү һ. б. ш. максатлар өчен кулланыла).

ЛАБЫРДАУ *ф. гади. с.* Юк-барны сөйләү, лыгырдау.

ЛАБЫРДЫК *с. гади с.* Такылдык, тел бистәсе.

ЛАБЫР-ЛОБЫР *аваз. ияр. сөйл.* Артык ачык булмаган авазлар чыгарып, ашыгып сөйләшү тавышын белдерә.

Лабыр-лобыр килү — шундый авазлар чыгарып сөйләү.

ЛА'ВА I *и.* Вулканнан (янар таудан) атылып чыга торган кызу сыек масса. *Тауның башы тишелеп, --- җир өстенә лава дип атала торган сыеклык, утлы мәгъдәннәр вә газлар чыга башлый.* Ф. Әмирхан.

ЛА'ВА II *и. хәрби.* Дошманны фланглардан һәм тылдан уратып алу өчен атлы сугышчыларның атака вакытындагы сугышчан тәртибе; шундый атака ясау өчен төзелгән отряд.

ЛА'ВА III *и. махс.* Күмерне яки башка төрле казылма байлыкларны казу өчен җир астында озын итеп ясалган забой. *Лавага кереп җиткәч, лампам сүнеп, нишләргә белмичә аптырап калуымны язып тормыйм.* Ф. Хөсни.

ЛАВА'НДА *и. бот.* Зәңгәр, күк яки шәмәхә төстәге чәчәк ата торган хуш исле мәңге яшел куак яки үлән үсемлек (медицинада, парфюмериядә кулланыла).

ЛАВИ'НА *и.* **1.** Тау башларыннан бик зур көч белән ишелеп төшә торган кар яки боз өеме.

2. *күч.* Ашкынып хәрәкәт итә торган нәрсәләр турында әйтелә. *Мондый очракларда электр бушануы булганда ионнар һәм электроннар лавинасы барлыкка килә.* Физика.

ЛАВИ'РОВАТЬ: **лавировать итү** *сөйл.* — 1) каршы җилне әле уңнан, әле сулдан исәрлек итеп, җилкәнле көймәне алга алып бару; || Алда очраган киртәләрне читләтеп, зигзаглар ясап хәрәкәт итү, алга бару; 2) *күч.* хәйлә белән бик оста эш итеп, авыр, кыен хәлдән чыгарга тырышу.

ЛА'ВКА *и. сөйл. иск. к.* кибет. [*Шәриф*] *үзләренә якын лавкадан ике кадак икмәк белән бер кап шырпы, өч мыскал чәй алып кайтты.* М. Гафури.

ЛАВР *и. бот.* Көньякта үсә торган, хуш исле озынча яфраклы мәңге яшел куак яки агач; дәфнә агачы. *Төрле пальмаларны, лаврларны, фикусларны һәм бүтән каучуклы үсемлекләрне лианалар чорнап алып, тоташ бер үсемлек стенасын тәшкил итәләр.* Физ. геогр.

Лавр веногы — 1) спортның нинди дә булса төрендә дөньяның абсолют чемпионы исемен яулап алган кешегә бүләк итеп тапшыру өчен лавр яфракларыннан үрелгән венок; 2) җиңү, триумф билгесе (символы) итеп кулланыла. **Лавр чиясе** *бот.* — гөлчәчәкләр семьялыгыннан көньякта үсә торган һәм җимеше чияне хәтерләткән, яфраклары хуш исле мәңге яшел куак яки агач. **Лавр яфрагы** — ашамлык хәзерләгәндә яки яшелчә, гөмбә һ. б. ш. маринадлаганда аш тәмләткеч буларак кулланыла торган киптерелгән лавр яфрагы.

ЛА'ВРА *и.* Турыдан-туры иң зур чиркәү властена (синодка) буйсынган, ирләр яши торган зур монастырь.

ЛАВСАН *и.* Синтетик тукыма җитештерү өчен нефть продуктларыннан ясалган җеп. *Нитрон һәм лавсан кушылган йон тукымалар --- эшләп чыгаруны арттырырга* [*кирәк*]. Соц. Тат. || *с. мәгъ.* Шундый җептән тукылган материалдан тегелгән. *Лавсан күлмәк. Лавсан чалбар.*

ЛАВЫЛДАП *рәв. сөйл.* Яңгыратып, үзенә бертөрле яңгыраш белән, кычкырып. *Ярулла --- лавылдап сөйли.* М. Фәйзи. [*Аблайның*] *тыштан ук сүгенгән тавышы ишетелә, --- [ул] лавылдап: „Алланың каты каһәре суккыры",— [дип кычкыра].* Н. Исәнбәт.

ЛАГ *и. махс.* **1.** Судно йөрешенең тизлеген яки узган юлының озынлыгын билгели торган навигация приборы.

2. Суднолың борты.

ЛА'ГЕРЬ *и.* **1.** Торак пунктлардан читтә, ачык һавада палаткалар корып, вакытлыча гаскәр урнашкан җир. *Курсантның вакыты аз, лагерьга, маневрга китәр чак җитеп килә иде.* Г. Ибраһимов. *Безнең лагерьга көн саен берничә йөз хатын килә. Гәрчә аларны лагерьга кертмиләр, ләкин командир рөхсәте белән боецлар үзләре коймага киләләр һәм сөйләшәләр.* М. Җәлил. || Поход вакытында гаскәр туктаган урын. *Баш күтәргән крепостной крестьяннарның юлбашчысы Пугачев күпмедер вакыт Бөгелмә тавында лагерь корып торган.* Г. Әпсәләмов. || Гаскәр урнашкан позиция. *Дошман лагереннан — дот, дзотларыннан, яшерен пулемет, туп ояларыннан безгә каршы ут ачылды.* Ә. Айдар.

2. Вакытлыча тора (яши) торган урын. *Менә инде боз лагеренда алты кеше, сигез эт кенә кала.* А. Алиш. *Шмидт лагерена Самолетлар очып баралар.* Ф. Кәрим. || *сөйл. к.* пионер лагере. *Беренче сентябрь якынлашты — лагерьлардан, санатори-йлардан балалар кайта башлады.* Г. Минский.

3. Авылдан ерак урындагы көтүлекләрдә терлекләрне ябып тоту өчен җәйге киртә абзар; утар. *Элекке елларда „Яңа юл" колхозының Ык елгасы буендагы Садак тавы итәгендә урнашкан җәйге лагере районда үрнәк итеп күрсәтелә иде.* Соц. Тат.

4. Әсирләр, тоткыннар яши торган урын. *Әсирләр лагеренда бер иптәшем белән фажигале очрашуга карата язылган бу шигырьне күп әсирләр үзләренең дәфтәрләренә күчереп алганнар иде.* А. Алиш. — *Узган ел миңа хезмәт белән төзәтү лагеренда шефчы укытучы булырга туры килде.* А. Шамов.

5. *күч.* Иҗтимагый-политик группа, агым, юнәлеш; бердәй карашта торган, мәсләктәш кешеләр төркеме. *Шулай итеп, казачийлар үзләре дә ике лагерьга аерылып баралар.* Ш. Камал. *Иске тормышның карт имәннәреннән булган Вәли бай Хәсәнов та, мал-милкеннән аерылып, революциягә дошман як лагерьда кала.* Г. Нигъмәти.

ЛАГУН *и. сөйл.* Агач чиләк; кечкенә агач мичкә. [*Шәйсолтан*] *арбаларның арткы күчәрләренә тагылган дегет лагуннарын селкетеп күрсәтте.* С. Рафиков.

ЛАГУ'НА *и. геогр.* 1. Диңгездән су, дулкын китергән ком, вак таш өеме белән аерылып барлыкка килгән сай сулы култык яки күл.

2. Мәрҗән утравы белән яр арасындагы диңгез суы яки мәрҗән утравы эчендәге сулык.

ЛАГЫР-ЛОГЫР *аваз изр. сөйл.* Аш, ботка яисә су, сөт һ. б. ш. кайнаганда чыккан тавышны белдерә.

Лагыр-логыр килү — шундый тавыш чыгарып кайнау.

ЛАГЫРТ-ЛОГЫРТ *аваз изр.* Чокырлы-чакырлы пычрак юлдан авыр йөк төяп барганда майланмаган арба тәгәрмәче чыгара торган тавышны белдерә.

ЛА'ДАН *и.* Кайбер тропик агачлардан алына торган хуш исле сумала (чиркәүдә гыйбадәт вакытында төтәтү өчен кулланыла). [*Рим папасы*], *Капиталның дары төтененә Катнаштырып ладан төтенен, Советларга поход ясау өчен Җыймак була дошман төркемен.* М. Гафури.

ЛАДЬЯ *и. махс.* Манара (башня) рәвешендә ясалган, шахмат тактасында туры линия буенча аркылыга һәм буйга йөри ала торган фигура; тура.

ЛАЕК *с.* Нинди дә булса берәр таләпкә җавап бирерлек, шул таләпкә туры килгән, шундый сыйфатка ия булган. *Гыйлажи да, Бикмулла да - - - яшь солдат янына [кунакка] чакырып алырга иң лаек кешеләр.* Ә. Еники. || Нәрсәгә дә булса яраклы дип табылган; тиешле яки яраклы дип саналган.— *Бу кыйммәтле, матур алмаз фәкать ханга лаек малдыр.* М. Гафури. | *хәб. функ. „Кара урман" [көе] буыннардан Буыннарга лаек күчәргә.* Ш. Маннур. *Кеше лаек киңрәк, зур тормышка, Хужа булсын кеше кояшка!* Н. Исәнбәт.

Лаек булу — 1) берәр таләпкә җавап бирү, шундый сыйфатка ия булу. [*Искәндәр:*] *Малайга кызыбызны бирергә күнгән булып, тик, безгә кияүлеккә лаек булу һәм халык арасында йөзебезне аклау өчен дип, Казанга барып ике ел укып кайтуын шарт иттек.* М. Фәйзи; 2) игътибарга алырлык, хөрмәтләрлек булу турында. *Өчесе дә батыр булган, Акыллы һәм лаек булган сөеп кararга.* Ә. Исхак.

ЛАЕКЛЫ *с.* 1. *к.* лаек. *Мин тавыш бирдем илемнең Лаеклы улларына.* Ә. Ерикәй. *Бу инде аның мондагылар арасында ихтирамга иң лаеклы кеше икәнен күрсәтә иде.* А. Шамов.

2. *рәв. мәгъ.* Тиешле рәвештә, тиешенчә; ничек кирәк шулай. *Мәскәү дә, уяулыгын киметмичә, киеренкелеген әз генә дә йомшартмыйча, дошманны һәр сәгать, һәр минут лаеклы каршыларга хәзер торды.* Г. Гобәй.

Лаеклы булу — *к.* лаек булу. *Лаеклы бул туган халкыңа.* Г. Хуҗиев.

ЛАЕКЛЫК *и. сөйл. к.* лаеклылык.

ЛАЕКЛЫЛЫК *и.* Лаеклы булу.

ЛАЕКСЫЗ *с. сөйл.* Нинди дә булса берәр нәрсәгә, эшкә һ. б. ш. лаек булмаган. *Ихтирамга лаексыз кеше ул минем күршем.* Сөйл.

ЛАЕШ: лаеш шулпасы (суы) эчү — бик зур авырлыклар кичерү, күп кыенлыклар күрү. *Кыяметдин бабай дөньяның ачысын-төчесен күп татыган, лаеш шулпасын күп эчкән карт иде.* М. Хәсәнов. **Лаешта булмаган** — авырлыклар күрмәгән, кыенлыклар кичермәгән.

ЛАЖ *и. махс.* 1. Капиталистик илләрдә: кыйммәтле кәгазьләрнең (акцияләрнең, облигацияләрнең һ. б. ш.) номиналь кыйммәте белән чагыштырганда курсы күтәрелү.

2. Кәгазь акчаларның кыйммәте төшкән вакытта, алтын акчаның номиналь кыйммәтенә өстәмә түләү.

ЛАЗ *и.* Грузиннарга кардәш булган, Грузиядә һәм Төркиядә яши торган бер халык атамасы; шул халыкның бер кешесе. *Мәскәүдә икмәк пешерүче лазлар әйтеп бетергесез күп.* Соц. Тат.

ЛАЗАРЕТ *и.* Гаскәри часть карамагындагы авырулар ятып дәвалана торган кечерәк госпиталь. *Озак та үтмәде, яралыларны, санитар арбаларга салып, зур бер лазаретка китереп төшерделәр.* М. Гали. — *Алар дивизиясенең лазаретында - - - каты яралы бер татар кызы яткан.* А. Шамов.

ЛАЗЕМ *с. иск.* Кирәкле, тиешле, зарур. *Лазем эш.* | *рәв. мәгъ. Ул моны ачыктан-ачык әйтмәсә дә, яшерергә дә лазем күрми иде.* Г. Ибраһимов. | *хәб. функ. Менә шуңа күрә дә мәктәп-мәдрәсә бәхәсләре кузгатылганда [сүз] иң әүвәл шушы тарафтан башланырга лаземдер.* Ф. Әмирхан.

Лазем булу — кирәк булу, тиеш булу. *Бу җирдә хөрмәтле укучыларыбызга Харбин шәһәрен тәгъриф итмәк лазем булды.* Ш. Мөхәммәдев.

ЛА'ЗЕР *и. махс.* Көчле һәм бик нечкә яктылык юлы барлыкка китерә торган яктылык дулкыннарын нурландыручы генератор. *Лазер белән операция ясарга мөмкин.*

ЛАЗЕМЛЕК *и. иск.* Тиешлек, зарурлык.

ЛАЗУРИТ *и. махс.* Ачык зәңгәр төстәге минерал (төрле бизәк әйберләре ясауга китә). *Памирда алтын, лазурит, тау хрустале очрый.* СССР экон. геогр.

ЛАЗУРЬ *и.* Ачык зәңгәр төстәге буяу.

ЛАЗУ'ТЧИК *и. иск. сөйл.* Сугыш хәрәкәтләре вакытында дошман тылына үтеп кергән күзәтче; шпион. [*1812 елгы Ватан сугышында*] *халык лазутчикларны, шпионнарны тоткан.* СССР тарихы. *Без инде берәр лазутчик иптәшенә шартлы сигнал бирә торгандыр дип уйлыйбыз.* Р. Батуллин.

ЛАИХӘ *и. иск. к.* проект. *Бу көннәрдә - - - мәктәпләр лаихәсе ясар өчен бер комиссия сайладылар.* Ф. Әмирхан.

ЛАЙ I. *и.* 1. Сазда, акмый яки акрын ага торган сулыкларда йөзеп йөри торган яки төпкә ябышкан суүсемнәр. *Лаеш суы ул шулай: Асты ләм дә өсте лай.* Н. Исәнбәт. *Лайга баткан „Шатур" сазыннан Совет иле 32 мең киловаттлы электрик уты кабызган.* Ф. Кәрим.

2. *диал. к.* ләм I (1 мәгъ.). *Пычракта йөреп, аяк вә балтырлар кап-кара лайга буялып бетә иде.* Ак юл. *Буаның лай утырган төбе һәм уйсулыкларда чапырдашкан вак балыклары күренгәнче су сипте-ләр.* А. Гыйләҗев. *Язгы кар сулары лай тутырган тамчы эзенә.* С. Рафиков.

ЛАЙ II *кис.* Җырда, бигрәк тә озын җырларда, текстны көйнең ритмикасына туры китерү өчен кулланыла торган сүз. *Кондыз лай бүркем су булды, Исмен лә белмәс бер егеткә Асыл сөякләрем хур булды.* Н. Исәнбәт. *Кара урман аша лай, Кошлар сайраша лай, башлар адаша.* Җыр.

ЛА'ЙКА I *и.* Ау, йөк тарту, болан көтүләрен саклау өчен файдаланыла торган төньяк этесе.

ЛА'ЙКА II *и.* Кәжә, сарык тиресеннән эшләнә торган йомшак күн. || *с. мәгъ.* Шундый күннән тегелгән. *Кара лайка перчатка эчендә тагын да нечкәрәк, тагын да кечкенәрәк, нәфисрәк булып күренгән аның сул кулында кечкенә генә сары күн саквояж.* К. Тинчурин.

ЛАЙЛА *и.* 1. Кайбер хайваннар яки үсемлекләр тарафыннан бүлеп чыгарыла һәм тотканда кул шуа торган куе сыекча. [*Балык*] *таңкәләренең өсте юка лайла белән капланган, бу лайланы тире бизләре*

бүлеп чыгара. Зоология. || Кешедә кайбер эчке органнарның өслегенә бүленеп чыга торган шундый ук сыекча. *Борын куышлыгы бизләреннән бүлеп чыгарылган лайла бирегә керә торган һавадагы бактерияләрнең тереклек эшчәнлеген киметә.* Анатомия. [*Нуруллин*] *авызында ниндидер лайла, тәмсез нәрсә барлыгын сизде.* А. Шамов.

2. *диал. к.* ләм I (1 мәгъ.).

ЛАЙЛАЛАНУ *ф.* Лайла белән капланы, лайла ябышу. *Явымлы көннәрдә* [*валуй*] *эшләпәсенең өсте лайлалана.* Робинзон эзл. *Хәйрүш, лайлаланудан агач кайрысы кебек каткан балагын кайтарып, гөбедәй шешкән аягын күрсәтте.* М. Хәсәнов.

ЛАЙЛАЛЫ *с.* 1. Лайла белән капланган, лайла ябышкан. *Лайлалы балык.*

2. *диал.* Ләмле, ләм утырган. — *Көн урталарында сазаннар, кырыйга якын килеп, лайлалы балчыкка чумып торалар.* Ш. Камал.

Лайлалы гөмбә — хлорофилы булмаган иң түбән төзелешле үсемлек. **Лайлалы тышча (сүрү)** — кайбер органнарның өслегенә лайла бүлеп чыгара торган тышча, катлау. *Томау төшкәндә (борын куышлыгының лайлалы тышчасы ялкынсынганда) лайланың күп чыгуы һава белән кергән бактериягә каршы саклану реакциясе була.* Анатомия. **Лайлалы шешенү** — бөтен тән күбенүдән гыйбарәт чир. *Кайчакта калкансыман биз гормонны нормадан ким чыгара һәм кеше лайлалы шешенү белән авырый.* Анатомия.

ЛАЙЛАЧ: лайлач әкәм-төкәм *зоол.* — моллюсклар отрядыннан кабырчыгы юк диярлек умырткасыз хайван; *русчасы:* слизняк. *Орхидеяның --- чәчәкләре лайлач әкәм-төкәмнәр һәм хәтта кечкенә генә кошлар — колибрилар ярдәмендә дә серкәләнәләр.* Робинзон эзл.

ЛА'ЙНЕР *и.* 1. Океанда яки диңгездә билгеле бер линиядә йөк һәм пассажирлар ташу өчен тиз йөрешле зур судно.

2. Регуляр рейслар башкара торган күп урынлы самолет.

ЛАК I *и. этн.* Дагстан АССРда яшәүче аерым бер кавказ халкының атамасы; шул халыкның бер кешесе.

ЛАК II *и.* Берәр предметның өслеген буяганда ялтыравык каты элпә барлыкка китерә торган сыекча — спиртта, скипидарда яки үсемлек маенда эретелгән сумала. *Спиртлы лаклар.* □ *Химик эшкәртү юлы белән нефтьтән --- лаклар, дару матдәләре эшләп чыгарырга мөмкин.* Химия. *Кыбырсынып торган таза күк айгырны каралы-кызыллы лак белән буяган --- пролеткага җигеп --- шәһәр уртасыннан узып китүе үзе нәрсә тора!* Ә. Фәйзи. || Шул сыекчаның предмет өслеген каплап, аңа ялтыравык биргән катлавы, элпәсе. *Рояльнең лагы кубу.* □ *Машина лаклары чатнап-чатнап куба.* Э. Касыймов.

Лак агачы — кайрысыннан лак өчен сумала алына торган тропик агач. *Япон утрауларының көньяк өлешендә --- лак агачлары, бамбук, әре ак чәчәкле магнолия, камелия куаклары үсә.* Дөнья кис. геогр.

ЛАКАЕП: лакаеп утыру *гади с.* — бик иркен һәм ямьсез рәвештә җәелеп утыру, киңәеп утыру.

ЛАКАН *и.* Юынтык сулар салу, кул юу һ. б. ш. өчен хуҗалыкта кулланыла торган зур агач савыт. *Батыргали агай, --- аягы абынып, бер лаканга барып батты.* Ш. Мөхәммәдев. *Сәлим өйгә кереп, чыланган киемнәрен салып, лаканга сыга-сыга, җылы мич кырыена элеп куйды.* Г. Гобәй.

ЛАКАУ *ф. гади с.* 1. Тел белән ялап алып эчү (кайбер хайваннар турында). *Мәче сөтне лакый гына.* Сөйл.

2. *күч. хурл.* Эчү, күп эчү (аракы, исерткеч эчемлекләр эчү турында). — *Каргалар үләксә ашамаган, ә син лакарга өлгергәнсең.* Ш. Камал.

ЛАКЕЙ *и.* 1. *иск.* Элекке вакытта рус дворяннары, байлары өендә яисә ресторанларда, гостиницаларда һ. б. ш. урыннарда хезмәт итүче. *Бу язучылар әүвәлдә бәгъзесе русларда артельщик, лакей булып хезмәт иткән --- адәмнәрдән гыйбарәттер.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *күч.* Кемгә дә булса ярарга тырышучы, тәлинкә тотучы ялагай. [*Солдат:*] *Буржуйларны гына түгел, буржуйлар сыбызгысына биюче ялтыравыклы погонлы лакейларны да яхшы беләбез.* Ш. Камал. *Безнең буржуазиябез соңгы көннәргә хәтле рус капиталына лакей булды.* Ф. Әмирхан.

ЛАКЕЙЛАНУ *ф.* Ялагайлану, тәлинкә тоту.

ЛАКЕЙЛА'РЧА *рәв. күч.* Ялагайланып, юмакайланып. *Лакейларча кылану.* □ *Иреннәрем иркемнән башка кызганыч һәм җирәнеч бер елмаю белән елмаялар, күзләрем лакейларча карый башлый.* С. Җәләл.

ЛАКЕЙЛЫК *и.* 1. *иск.* Лакей булу, лакей хезмәте. *Лакейлыкны ташлау.*

2. *күч.* Тәлинкә тоту, ялагайлык, юмакайлык.

Лакейлык итү — лакейлану. *Безнең аристократиябез (әгәр мирзаларны шулай дип атарга яраса) Казан ханлыгының соңгы дәвереннән башлый Мәскәү князьлегенә лакейлык итте.* Ф. Әмирхан.

ЛАКИРО'ВКАЛАУ *ф. сөйл. к.* лаклау.

ЛАКИРО'ВКАЧЫ *и. сөйл. к.* лаклаучы.

ЛАКИРО'ВЩИК *и. сөйл. к.* лаклаучы.

ЛАКЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* лаклау.

2. Лак белән буярга яраклы булу. *Бу агач яхшы лаклана.*

ЛАКЛАУ *ф.* Нинди дә булса предметның өслеген лак белән каплау, лак белән буяу. *Морилка сөрткәннән соң әйбер кисәкләрен киптерәләр, аннары балавыз сөртәләр һәм лаклыйлар.* Йорт эшләре. *Лаклау, йомшак мебель эшләү өчен ике конвейер линиясе һәм 300 дән артык яңа җиһаз куелды.* Соц. Тат.

ЛАКЛАУЧЫ *и.* 1. Лаклау остасы, лаклау эше белән шөгыльләнүче кеше.

2. *күч.* Кимчелекләрне яшереп калдыручы, чынбарлыкны бизәп, шомартып күрсәтүче. *Шигырь яздым Мактап яхшы колхозны, Тәнкыйтьчеләр тик бер карап бактылар, „Лаклаучы" дип „матур" исем тактылар.* Каз. утл.

ЛАКЛЫ *с.* Лакланган, лак белән капланган. *Хәлим кара лаклы зур тарантас кузласына утырган.* Г. Гобәй. [*Мәрфуганың*] *аягында биек үкчәле, ялтырап торган лаклы туфли иде.* Г. Ахунов.

ЛА'КМУС *и.* 1. *махс.* Диңгез лишайникларыннан табыла һәм кислота тәэсирендә — кызыл, селте тәэсирендә күк төскә керә торган буяу матдәсе. *Һәр пробиркага лакмус эремәсе тамызыгыз һәм аның төсе үзгәрүен билгеләгез.* Химия. || *с. мәгъ.* Составында шундый матдә булган. *Лакмус буяулар.*

2. *сөйл. к.* лакмус кәгазе.

Лакмус кәгазе — лакмус эремәсе сеңдерелгән, селтеләрне һәм кислоталарны билгеләү өчен реактив буларак кулланыла торган фильтрлау кәгазе. *Зәңгәр лакмус кәгазен ашказаны сыекчасына чылатсаң, ул кызара.* Анатомия.

ЛАКОНИЗМ *и. кит.* Сөйләмнең кыскалыгы, аз сүз белән тирән мәгънә бирелү.

ЛАКОНИК *с. кит.* Күп сүзле булмаган, кыскалык, җыйнаклык белән аерылып торган. *Лаконик сөйләм.*

ЛАКТА'ЦИЯ *и. махс.* Имезүче ана хайваннарда сөт бизләренең сөт бүлеп чыгаруы; сөт бүлеп чыгару дәвам иткән чор. *Һәр айдагы савымны бергә кушу юлы белән сыерның лактация чорында һәм 300 көндә күпме сөт бирүе билгеләнә.* Сөт терлекчелеге...

Сөтен ташлап торган чорда яхшы ял иткән сыер киләсе лактациядә --- сөтне күбрәк бирә. Йорт эшләре.

ЛАКТОБАЦИЛЛИН *и. махс.* 1. Сөтне әчетеп, аңа дәвалау үзенчәлеге бирә торган махсус гөмбәчек, бактерия.

2. Шундый гөмбәчек ярдәмендә әчетеп оетылган сөт.

ЛАКТО'ЗА *и. махс.* Имезүче хайваннарның сөтендә булган шикәр, сөт шикәре (медицинада кулланыла).

ЛАКТО'МЕТР *и. махс.* Сөттәге суның һәм майның процент исәбе белән микъдарын билгеләү өчен шкалалары булган озынча пыяла савыттан гыйбарәт прибор.

ЛАКТОСКОП *и. махс.* Сөтнең куелыгын, майлылыгын үлчи торган прибор.

ЛАКЫЛДАУ *ф. сөйл. к.* лыкылдау.

ЛАКЫЛДЫК *ф. сөйл. к.* лыкылдык.

ЛАКЫР-ЛОКЫР *аваз. ияр. к.* лагыр-логыр.

ЛАЛӘ *и.* Лаләчәләр семьялыгыннан әре кыңгырау чәчәкле, суганчалы күпьеллык үсемлек; *русчасы:* тюльпан. *Лалә̀ләрне бигрәк тә --- матур чәчәкләре өчен үстерәләр.* Йорт эшләре. *Бар табигать, бар агачлар, Сандугачлар, лалә̀ләр — Барысы да тәкрар итәләр.* Һ. Такташ.

Лалә чәчәге (гөле) — *к.* лалә. *Далада яз көне --- лалә чәчәкләре --- үсеп чыга.* СССР физ. геогр.

ЛАЛӘГӨЛ *и. сөйл. к.* лалә.

ЛА'МА I *и.* Дөяләр семьялыгыннан Көньяк Америкада яши һәм йөк ташый торган өркәчсез хайван. *Анд тауларында --- ламаларның төрле төрләре --- яши.* Дөнья кис. геогр.

ЛА'МА II *и.* Тибетта һәм Монголиядә будда дине монахы.

ЛАМАИЗМ *и.* Будда диненең XIV йөздә Тибетта һәм Монголиядә барлыкка килгән төре.

ЛАМАИСТ *и.* Ламаизм тарафдары.

ЛАМАНТИН *и.* Үлән ашаучы сиреналар отрядыннан Атлантик океанның Африка һәм Көньяк Америка яр буйларында яши торган имезүче диңгез хайваны; диңгез сыеры.

ЛАМАРКИЗМ *и.* Француз галиме Ж. Б. Ламаркның тере табигатьтә эволюцион үсеш турындагы тәгълиматы.

ЛАМБРЕКЕН *и. махс.* 1. Тәрәзә, ишек башында, өй кыегында һ. б. ш. урыннарда агачтан сырлап ясалган бизәк.

2. Тәрәзә, ишек драпировкасының кайма һәм башка бизәкләр белән зиннәтләнгән өлеше.

ЛАМИНА'РИЯ *и. махс.* Кайбер төрләре (мәсәлән, диңгез кәбестәсе) ашамлык итеп кулланыла торган әре диңгез суүсемнәре.

ЛА'МПА *и.* 1. Яктырту өчен хезмәт итә торган төрле формадагы һәм төзелештәге прибор. *Керосин лампасы. Сукыр лампа. Өчле лампа. Унлы лампа.* □ *Тышта әле караңгы төшеп җитмәгән булуга карамастан, өйдә асылмалы лампага ут алынган.* М. Әмир. *Стена буенда — кадакка эленгән шахта лампалары, почмакта — кәйләләр.* Ш. Камал.

2. *к.* лампочка. *Баганаларда --- лампалар кабынды.* А. Алиш. *Аллы-зәңгәрле электр лампалары белән яктыртылган вагонның урта купесында киң өлгеле тәрәзәдән Юныс Вәлишинның йөзе чагылып китте.* К. Нәҗми.

Лампа куыгы (пыяласы, торбасы) — *к.* куык 4. *Тегәрҗеп киләбе, запас лампа пыяласы, счет, кара шәшәсе шикелле әйберләр, әлбәттә, исне китәрми.* Ш. Камал. **Лампа мае** *иск сөйл.* — керосин.

ЛАМПА'ДА *и.* Икона алдында агач мае салып яндырыла торган фильтәле кечкенә савыт.

ЛАМПА'ДКА *и. к.* лампада.

ЛА'МПАЛЫ *с.* Электрон лампалары ярдәмендә эшли торган. *Лампалы көчәйткеч. Лампалы генератор.* □ *Лампалы алгычлар арасында бер лампалылары иң гадиләрдән санала.* Радио сөюче . . .

ЛАМПАС *и.* Форма чалбарының ян як җөйләре буйлап тегелгән төсле бер яки ике буй тасма. *Күк лампаслы чалбар [аларның] казаклар икәнлеген белдереп тора.* Ш. Усманов.

ЛА'МПАЧЫ *и.* 1. Лампа производствосында эшләүче эшче, лампа ясаучы.

2. Лампалар белән яктырту эшен башкаручы эшче.

ЛАМПИОН *и. махс.* Төсле кәгазьдән яки пыяладан ясалып, иллюминация өчен кулланыла торган кечкенә фонарь.

ЛА'МПОЧКА *и.* Вольфрам чыбыкны ток белән кыздыру нәтиҗәсендә яктылык бирә торган пыяла баллон, электр лампасы. *Электр лампочкасы, төбе белән бергә кубып, идәнгә төшеп шартлады.* К. Тинчурин. *Артык кызуга китсә, бу лампочка үзеннән-үзе сүнә.* А. Алиш.

ЛАМУТ *и.* Эвеннарның элекке исеме.

ЛАНГЕТ *и. махс.* Юка гына итеп киселгән озынча ит кисәкләреннән кыздырып әзерләнгән ашамлык.

ЛАНГУСТ *и. зоол.* Кыскычсыз, каты кабырчыклы, ун аяклы, ите ашарга ярый торган, озын мыеклы диңгез кысласы.

ЛАНДО *и. кит.* Өсте ачыла торган дүрт урынлы карета.

ЛАНДРИН *и. иск. к.* монпаси. *Валерикны алырга кергән апа барысына да бирәр ландрин биреп чыкты.* Г. Гобәй.

ЛАНДРИНЛАНУ *ф. сөйл. к.* кәнфитләнү. [*Батырхан:*] *Гафу итегез, туташ, сүзләрегезгә төшенә алмыйм.* [*Рокыя:*] *Ярый, ярый, ландринланмагыз.* К. Тинчурин.

ЛАНДСКНЕХТ *и.* Көнбатыш Европада XV — XVII гасырларда ялланган солдат. || Гомумән ялланган сугышчы, солдат.

ЛАНДТАГ *и.* 1. Урта гасырларда Германиядә феодаль князьлекләрдәге җирле парламент. *Бу дәүләтләрнең һәрберсе үзенең берникадәр мөстәкыйльлеген саклый. Аларда үзләренең хөкүмәтләре, үзләренең монархлары һәм үзләренең җирле парламентлары— ландтаглар кала.* Яңа тарих.

2. Германия Федератив Республикасында һәм Австриядә аерым өлкәләрнең законнар чыгарырга хокуклы иң югары органы.

ЛАНДШАФТ *и.* 1. Берәр табигый урынның гомуми күренеше, пейзаж. *Айдагы ландшафт гаять күп төрле: анда̀ йөзләрчә километрга сузылган тигезлекләр, 9000 м биеклеккә күтәрелгән таулар, 200 км га кадәр диаметрлы кратер-цирклар* [*бар*]. Космик ракеталар.

2. *махс.* Үзенә генә хас рельефы, климаты, туфрагы, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы булган җир өслегенең бер кисәге. *Дала ландшафты. Урман ландшафты.*

ЛА'НДЫШ *и.* Лаләчәләр семьялыгыннан озынча яфраклы һәм бик кечкенә генә кыңгыраучыкларга охшаган хуш исле ак чәчәкле үлән үсемлек; әнҗе чәчәк. *Урал ландышының ак чәчәге Макталадыр матур дан белән.* Ш. Маннур. *Ландыш, ромашка --- дару итеп файдаланыла.* Ботаника.

Ландыш агачы — ландыш чәчәкләре исе килгән ак чәчәк ата һәм көньякта үсә торган мәңге яшел агач яки куак.

ЛАНОЛИН *и.* Сарык йонын махсус ысул белән юганда алына һәм медицинада, техникада, косметикада кулланыла торган сары төстәге май. [*Саклагыч*] *пудраның составына 50 грамм тальк һәм 2,5 грамм ланолин керә.* Йорт әшләре.

ЛАНОЛИНЛЫ *с.* Ланолин кушылган, составында ланолин булган. *Ланолинлы сабын.*

ЛАНТАН *и.* Һавада оксидлаша һәм кыздырганда яна торган сирәк таралган элемент. *VI периодта --- өч валентлы лантаннан башка тагы бер-берсенә бик охшаган ундүрт металл урнашкан.* Химия.

ЛАНЦЕТ *и.* Хирургиядә кулланыла торган үткен очлы, ике йөзле пычак. *Әнә, инструментлар шкафында, көмештәй ялтырап, әле кулга да алынмаган пинцетлар, ланцетлар, шприцлар --- һәм башкалар* [*яңа*]. Г. Минский.

ЛАНЦЕ'ТНИК *и.* Формасы белән ланцетка охшаган, ярым үтә күренмәле, балык сыман диңгез хайваны.

ЛАНЬ *и.* Боланнар семьялыгыннан зифа гәүдәле йөгерек хайван (боланның бер токымы). *Урта диңгез буенда кыргый хайваннар аз сакланып калган. Алардан лань, чүл бүресе, --- кыргый кроликлар очрый.* Дөнья кис. геогр.

ЛАОСЛЫ *и.* Лаоста яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе.

ЛАП *аваз. ияр.* Берәр әйбер җиргә килеп төшкәндә яки кинәт егылганда, утырганда һ. б. ш. вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лап итеп — шундый тавыш чыгарып, кинәттән. [*Байтирәк:*] *Мөритем башы белән йөзтубән лап итеп лаканга чумды.* Т. Гыйззәт. *Ах-вах итеп Сәхипҗамал керә һәм лап итеп урындыкка утыра.* А. Әхмәт.

ЛАПАЕП: лапаеп утыру *диал.* — *к.* лакаеп утыру. — *Хәкимә ничек лапаеп утырып алган.* М. Фәйзи.

ЛАПАС *и.* Мал-туар, арба-чана, эш кораллары, утын һ. б. ш. нәрсәләрне кояштан, явым-төшемнән ышыклау өчен, баганаларга утыртылган, авыш итеп ябылган түбәле, бер яки ике ягы да ачык булган корылма (абзар белән рәттән дә, аерым да булырга мөмкин). *Тарантасны лапаска кертеп куйгач, Сабир бабай белән Газинур келәт бусагасына утырдылар.* Г. Әпсәләмов. *Колхоз арбаларын һәм авыл хуҗалыгы машиналарын кую өчен бөркәүле лапаслар ясалган.* М. Гали.

ЛАПИДАР *с.* Кыска һәм аңлаешлы, кыска һәм ачык итеп бәян ителгән (стиль, сөйләм). *Лапидар сөйләм.*

ЛАПИДАРЛЫК *и.* Лапидар булу, кыска һәм ачык итеп бәян ителгән булу. *Стильнең лапидарлыгы.*

ЛАПЛАНД *и. иск.* Саам халкының искергән атамасы. *Тундрада яшәүче лапландлар һәм эскимослар болан көтүләре асрыйлар.* Робинзон әзл.

ЛАП-ЛАП *аваз. ияр. к.* лап-лоп. *Ары лап-лап, бире лап-лап, киез каплап, сөңге саплап.* Табышмак.

ЛАП-ЛОП *аваз. ияр.* Аякны авыр итеп җиргә басып атлаганда яки йөгергәндә, авыр әйберләр җиргә төшкәндә һ. б. ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Каршыдан йодрыкларын төйгән хәлдә лап-лоп басып Сәлим мирза керә.* М. Фәйзи. *Урам буйлап кемнеңдер лап-лоп йөгереп килгәне ишетелә.* И. Гази.

ЛАПТА *и.* Ике төркемгә бүленеп уйнала торган туп сугу уенының бер төре. *Хәлимне кузна уены, лапта, кәшәкә таяк уеннары, футбол, балык тотулар үз эченә алып кереп китәләр.* Г. Гобәй.

Лапта туп — *к.* лапта.

ЛАПТЫРДАУ *ф. сөйл.* Зур аяк киеме киеп йөргәндә, берәр нәрсә бик каты җилфердәгәндә һ. б. ш. вакытларда үзенә бер төрле авазлар барлыкка китерү. *Зур итекләр атлаганда лаптырдый.*

ЛАПТЫРДЫК *с. сөйл.* Чамадан тыш зур булу аркасында лаптырдап торган (күбрәк аяк киемнәре турында). *Лаптырдык галош.* || Гомумән чамадан тыш зур кием турында. [*Хәят*] *өйдә киеп йөри торган лаптырдык күлмәгенең җиңнәрен бармак очлары гына күренеп торырлык итеп төшерде.* Ф. Әмирхан.

ЛАПТЫР-ЛАПТЫР *аваз. ияр. к.* лаптыр-лоптыр. *Лаптыр-лаптыр атлау.*

Лаптыр-лаптыр килү — *к.* лаптыр-лоптыр килү.

ЛАПТЫР-ЛОПТЫР *аваз. ияр.* Зур аяк киеме киеп йөргәндә, берәр нәрсә бик каты җилфердәгәндә яки очып барганда һ. б. ш. вакытларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Лаптыр-лоптыр бару.*

Лаптыр-лоптыр килү — *к.* лаптырдау.

ЛАПШЫК *с. сөйл.* Мускуллары эластиклыгын югалткан, сәлперәйгән. *Симез ат артык туйса, лапшык булыр.* Мәкаль.

ЛАПШЫКЛАНУ *ф. сөйл.* Лапшыкка әйләнү; мускуллар, тән сәлперәю.

ЛАПШЫРДАУ *ф. сөйл.* Сәлперәю, йомшару, эластиклыгын югалту (мускуллар, тире һ. б. ш. турында).

Лапшырдап тору — буш булу, бик зур булу (кием турында). *Дниләре лапшырдап торган киндер күлмәген кыстырган, яулыгын артка тартып бәйләгән.* М. Әмир.

ЛАПШЫРДЫК *с. сөйл.* **1.** *к.* лапшык;

2. Буш, лапшырдап торган (кием турында).

ЛАПШЫРУ *ф. сөйл. к.* лапшырдау.

ЛАПЫ *и. диал.* Урманда җиргә егылган агач.

ЛАПЫЛДАТУ *ф. сөйл.* **1.** *к.* лапылдау.

2. *к.* ләпелдәтү. *Дниләре --- калын иренен лапылдата-лапылдата балаларын тирги.* М. Әмир.

ЛАПЫЛДАУ *ф. сөйл.* **1.** Аякларны авыр итеп басып үзенә бертөрле тавыш чыгару.

2. *рәв. мәгъ. сөйл.* **лапылдап.** *к.* лап итеп. [*Галәви*] *чикмәннәре белән лапылдап идән астына барып төшә.* М. Гали.

ЛАПЫЛЫК *и. диал.* Урманның куе урыны; җиргә егылган агачлары күп булган урыны.

ЛАПЫР-ЛОПЫР *аваз ияр.* Атлаганда өс киемнәре озын булу аркасында яки алар җилдән җилфердәгәндә, берәр нәрсә җилләнгәндә һ. б. ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Ата казлар, милай чактагы кебек, муеннарын сузып егетнең артыннан лапыр-лопыр куып карасалар да, бик куркыта алмадылар.* И. Гази. || Су кергән аяк киеме белән яки сулы җирдән атлаганда барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лапыр-лопыр килү (итү) — шундый тавыш-авазлар чыгару. *Лапыр-лопыр килмәсен әле дип, күлмәк итәген шактый күтәреп бөрмәсенә кыстыра да, кызгылт ыштанын җилфердәтеп, алга таба төгәри ул алла карчыгы.* И. Рәмиев. *Күкрәген киереп, лапыр-лопыр итеп, аягындагы зур күн итекләрен көчкә күтәреп, Айнук килеп чык*[*ты*]. К. Тинчурин.

ЛАПЫРДАУ *ф. сөйл. к.* лапыр-лопыр килү.

ЛАР *и.* **1.** Азык-төлек һәм башка әйберләр саклау өчен зур агач әрҗә, өсәк. [*Газинур*] *бары үги әнисенең өйалдындагы лар капкачын каты япканын ишеткәч кенә уянды.* Г. Әпсәләмов. *Киң буралар һәм ларларның буш торуын күргән Гыймазов Сәхәпкә ризасыз караш ташлады.* С. Рафиков. || Тегермәндә тартылган он төшә торган зур тартма. [*Хәлим*] *яңадан тегермәнгә йөгереп кергәндә, этисе, лар янына басып, улактан аккан онны бармаклары белән уып тора иде.* И. Гази. || *сөйл.* Тартма, әрҗә. [*Кешеләр*] *юл тирәләрен сырып алган вак сатучыларның лар-*

ларын, кәрзиннәрен, ящикларын [*барып карыйлар*]. Ф. Әмирхан.

ЛАРЁК *и. сөйл.* Кечкенә генә кибет, сату итү палаткасы. *Ларёкның прилавкасы өстендә кунаклаган мәшһүр погромчы Мөхәммәтҗан Хафиз чехларның чеп-чи кяферлар булмаулары турында халыкка вәгазь сөйләп тора.* К. Тинчурин.

ЛАРЁКЧЫ *и.* Ларёкта сату итүче. [*Кариев*] *үзе башкара торган „шкафчы“ (хәзергечә әйтсәк, ларёкчы) ролен үтәү өчен Печән базарында Мөхәммәтҗан Хафизны өлге итеп өйрәнде.* И. Рәмиев.

ЛАРИНГАЛЬ *с. лингв.* Бугазда ясалган, бугазда барлыкка килгән (авазлар турында). *Ларингаль тартыклар* (мәсәлән, „тәэмин“, „тәэсир“ сүзләрендәге „э“ хәрефе белән белдерелгән аваз).

ЛАРИНГИТ *и. мед.* Бугаздагы лайлалы катлауның ялкынсынуы. *Хроник ларингит.*

ЛАРИНГО'ЛОГ *и.* Бугаз авырулары белгече — врач. || *сөйл.* Отоларинголог.

ЛАРИНГОЛО'ГИЯ *и. мед.* Бугазның анатомиясен, физиологиясен һәм авыруларын өйрәнә торган дисциплина, фән.

ЛАРИНГОСКОП *и. мед.* Бугазны тикшерү өчен озын сапка яссы көзге утыртылган прибор.

ЛАРИНГОСКОПИ'Я *и. мед.* Бугазны ларингоскоп ярдәмендә тикшерү.

ЛАРИНКС *и. мед., лингв.* Бугазның тавыш ярылары янындагы өлеше.

ЛАРК, ЛАРК-ЛАРК *аваз. ияр.* Берәр авыр әйберне кинәт ташлаганда яисә берәр авыр әйбер каты җиргә төшкәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Аркаларына ящиклар күтәргән грузчиклар, пароходка кереп, йөкләрен идәнгә ларк-ларк иттереп салдылар.* И. Гази.

ЛАР-ЛАР *аваз ияр.* Бертуктаусыз кычкырып сөйләшүне яки шундый сөйләшү тавышларын белдерә.

Лар-лар сөйләшү, лар-лар килү — шундый сөйләшүне аңлата.

ЛАР-ЛОР *аваз ияр. к.* лар-лар.

ЛАРС *аваз ияр.* Авыр предмет берәр җиргә килеп төшкәндә яисә аны берәр урынга китереп салганда барлыкка килгән тавышны белдерә.

Ларс итеп — шундый тавыш чыгарып. *Ларс итеп егылып төшү.*

ЛАРСЫЛДАП *рәв. сөйл.* Ларс итеп. *Ларсылдап егылу.*

ЛАРСЫЛДАТЫП *рәв. сөйл.* Ларс иттереп. *Хәерелбанат, Нигъмәткә арты белән генә әйләнеп, зур тушәкне ларсылдатып сәкегә салды.* К. Нәҗми.

ЛАРТ-ЛОРТ *аваз ияр.* Каты басып тиз йөргән вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Ларт-лорт йөрү.*

ЛАРЫЛДЫК *с. гади. с.* Ларылдарга яратучы, кычкырып сөйләшүче. *Ларылдык хатын.*

ЛАРЫЛДАУ *ф. гади с.* Кычкырып сөйләшү, бертуктаусыз сөйләшү.

ЛАСА *кис. сөйл. к.* лабаса („лабаса“ сүзеннән кыскарып килеп чыккан). *Һәркайчан тик тор, берәр ахмак адәм сүз сөйләсә, Бел, аңа сүз кайтарудан тик тору артык ласа.* Ш. Бабич.

ЛАСБЫН, ЛАСБЫР *с. диал.* Тузыган озын йонлы. *Ласбыр эт.* || Тузыган озын (чәч турында). *Ласбыр чәч.*

ЛАСБЫРДАП: ласбырдап тору *диал.* — тузыган булу; озын куе йонлы булу.

ЛАСБЫРЛАНУ *ф. диал.* Ласбыр хәлгә килү, ласбырга әйләнү.

ЛАС-ЛОС *аваз. ияр.* Салмак кына итеп авыр басып йөргәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. — *Гөбе юанлыгы аяклары белән лас-лос атлап ничек йөри икән бу бичара.* Г. Мөхәммәтшин.

ЛАССО *и.* Иректә йөргән хайваннарны тоту өчен Америкада көтүчеләр, аучылар куллана торган, очында шума элмәге булган аркан; корык.

ЛАСТ *и. махс.* Судноларның йөк сыешлыгын үлчәү өчен кабул ителгән йөк үлчәү берәмлеге (төрле илләрдә төрлечә).

ЛА'СТИК I *и.* Уң ягы ялтыравыклы киже-мамык тукыма (гадәттә кием эчлегенә куела).

ЛА'СТИК II *и.* Резина, каучук. || *сөйл.* Язганны бозар өчен резинка, бетергеч, бозгыч.

ЛАСТЫР-ЛОСТЫР *аваз. ияр. к.* лаштыр-лоштыр.

ЛАТ *и. махс.* Борынгы һәм урта гасырлар сугышчысының күкрәген һәм аркасын әүвәлге чорда салкын коралдан, соңыннан пулядан да саклый торган металл кием. *Англия укчылары бөтен Европада дан тотканнар. Аларның уклары хәтта калын тимер латларны да тишә алган.* Урта гас. тарихы.

ЛАТА'НИЯ *и.* Пальмалар семьялыгыннан киң җилпәзә сыман яфраклы декоратив үсемлек.

ЛА'ТЕКС *и. махс.* Каучук алына торган үсемлекләрнең сөт сыман согы (ясалма юл белән дә табыла).

ЛАТЕРАЛЬ *с. махс.* Янда урнашкан, яндагы (берәр органның янда, кырыйда урнашуын белдерә).

Латераль тартыклар *лингв.* — телнең кырыйлары (яны) буйлап чыккан һава агынтысы ярдәмендә ясалган тартык авазлар (мәсәлән, „л“ авазы).

ЛАТИН *и.* **1.** Борынгы Италий өлкәсендә — Лациумда яшәгән кеше (борынгы Италия кабиләсе кешесе).

2. *с. мәгъ.* Борынгы Римга, римлыларга караган, борынгы Римга, римлыларга бәйләнешле. *Латин мәкале. Латин культурасы.* □ *Рус теле белән иске латин теле* [*Җиһангирне*] *йөдәтәләр.* Г. Ибраһимов.

3. *с. мәгъ.* Латин әлифбасына караган, латин әлифбасыныкы булган. *Бу дәфтәргә русча гына түгел, латин хәрефләре белән дә бик күп чит сүзләр язылган иде.* А. Шамов.

4. *сөйл.* Латин теле. *Латин белән космографиядән* [*икеле*] *алма.* Ф. Әмирхан.

5. *иск.* Католик. *Латин чиркәве.*

Латин әлифбасы — Борынгы Римда кулланыла башлаган әлифба.

ЛАТИНИСТ *и.* Латин филологиясе белгече.

ЛАТИНЛАШТЫРУ *ф.* **1.** Латин телен һәм культурасын кертү. *Римлылар күп кенә җирле кабиләләрне латинлаштырдылар.*

2. Нинди дә булса алфавитны латин алфавиты белән алыштыру.

ЛАТИНЛАШУ *ф.* Латин телен һәм культурасын үзләштерү.

ЛАТИ'НЧА *рәв.* Латин телендә. *Латинча уку.* || *с. мәгъ.* Латин телендәге, латин телендә язылган. *Хәсән бу китаплар арасыннан --- латинча сарыф* [*морфология*], *французча кыйраәт* [*уку*] *китапларын алды.* Ф. Әмирхан.

ЛАТИНЧЫ *и. тар.* Латин алфавитын кертүне яклаган кеше.

ЛАТИФУ'НДИЯ *и.* Хосусый карамакта булган эре җир биләмәсе. *Алпавыт латифундияләре.*

ЛАТЛАУ *ф. диал.* Җайлау, көйләү; жайга китерү. *Юлбарыслар — уңга, Шаһи сулга атлый, Ләкин Шаһи үз хәйләсен һаман латлый.* З. Бәшири.

ЛАТЫЙФА *и. сөйл. иск.* Кызыклы, көлкеле, үткен мәгънәле кечкенә хикәя; мәзәк. *Н. Исәнбәт, Хуҗа Насретдинның төрле латыйфаларын бер җепкә тезеп, сюжетлы әсәр тудырган.* М. Җәлил.

ЛАТЫ-ПОТЫ *рәв. сөйл.* Телне начар, такы-токы белү турында. — *Ләкин минем русчам бик латы-поты, --- сала агае русчасы гына.* Ф. Әмирхан.

ЛАТЫШ *и.* 1. Латвия республикасында яшәүче төп халыкның атамасы; шул халыкның аерым бер кешесе. *Латышлар, литвалылар үзләренең илләренә [шул вокзалдан] --- юнәләләр.* Г. Гали.

2. *с. мәгъ.* Шул халыкка, аның культурасына, тормышына бәйләнешле. *Латыш теле. Латыш әдәбияты. Латыш сәнгате.*

ЛАТЫ'ШЧА *рәв.* Латыш телендә. *Латышча сөйләшү.* || *с. мәгъ.* Латыш телендәге, латыш телендә язылган. *Латышча китап.*

ЛАТӘФӘТ *и. сөйл. иск. к.* ләтафәт. *Язгы һаваның латәфәте өстенә кичкә каршы була торган аз гына салкынлык кушылып бертөрле рәхәт вә шатлык хис кылдырмакта иде.* Г. Ибраһимов.

ЛАУ: лау килү *диал.* — ду килү, ыгы-зыгы килү; шау-шу күтәрү. *Менә җен халык! Үзләре белән арбаларында буза кайнатып алып килгәннәр! Ире-хатыны бары да лау килә!* Н. Исәнбәт.

ЛАУЛАП: лаулап яну *диал.* — ялкын белән яну, ялкынланып яну, дөрләп яну.

ЛАУРЕАТ *и.* Фән, сәнгать һ. б. ш. өлкәләрдә аеруча зур хезмәт күрсәткән өчен бирелә торган мактаулы исем; шундый исем алган кеше. *Ленин премиясе лауреаты. Лауреат исемен бирү.*

ЛАФ *и. иск.* Мактану; буш сүз. *Лаф белән пылау пешмәс.* Мәкаль.

Лаф ору — 1) буш сүз сөйләү, юк-бар сүз сөйләү; сафсата сату. [*Байгильдиев*], *уң әсерларга кушылып китеп, үзенең пугач шартлатырлык гайрәте булмаса да, „террор" турында лаф орырга бик ярата иде.* К. Тинчурин. [*Бу мәкальне*] *өйләнүне юк эш дип лаф оручыларга әйтәләр.* Н. Исәнбәт; 2) мактану, шапырыну. *Хәтта ул узган җомга көнне кибете алдында җыелган яшьләр арасында, кызмача баштан, „Телим икән — Миңсылу минеке и вәссәлам!" — дип лаф орган.* Г. Минский.

ЛАФА *хәб. функ. гади с.* Берәр кеше өчен бик уңай, бик яхшы булган эш яки хәл турында. *„Болай булгач, лафа!" — диде Яруллин, кулларын угалап.* Ә. Еники.

ЛАФЕТ *и.* Артиллерия орудиесе беркетеп куела торган станок, җайланма. *Утырдым да пушка лафетына, Уйга калдым кичке тынлыкта.* Ф. Кәрим.

ЛАФЕТЛЫ: лафетлы ургыч — аеры урып-җыйганда игенне тезмәләргә урып сала торган ургыч.

ЛАФЕТЧЫ *и.* Лафетлы ургычта эшләүче. *Лафетчылар эшкә тотындылар.*

ЛАФЫЗ *и. иск. к.* ләфыз. [*Әпрәү:*] *Сиңа гаять гашыйк булып, --- бер-ике лафыз --- мәктүп язарга уйладым, дигән.* М. Фәйзи.

ЛА'ЦКАН *и.* Төймәләнә торган өске киемнең (мәсәлән, пиджакның) күкрәк өлешендәге кайтарма якасы. *Пиджак лацканы.* □ [*Атнабаевның*] *кулы урындык аркасына эленеп куелган пиджагына сузылып, аның лацканына тагылган орденын капшый.* Ф. Хөсни.

ЛАЧ I *аваз. изәр.* Бик каты итеп төкергән вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лач иттерү — шундый тавыш чыгару. [*Иблис*] *аракыга лач иттереп бер төкергән икән, табындагылар аны эчкәч, араларында адәмлек тә, туганлык та калмаган, имеш.* Н. Исәнбәт. *Ни өчендер бик каты мине тирги башлыйлар, лач иттереп йөземә төкерәләр.* С. Җәләл.

ЛАЧ II *рәв.* һәм *с.* 1. Бөтенләй, манма (юеш булу, чылану турында). *Юка пальто эчендәге коңгырт сатин күлмәк лач су булса да,* [*ул*] *теге як бүлмәгә тими китүдән җайсызланды.* К. Нәҗми. || Юеш, бөтенләй юеш хәлдә; сулы, дымлы. *Печәннәр лач булып яталар.*

2. Чи, бөтенләй чи (камыр ашы турында). *Ипи лач булган.*

ЛАЧКЫЛДАТУ *ф. сөйл.* 1. *к.* лачкылдау.

2. Сыек ашамлыкны ашаганда, чөмергәндә үзенчәлекле бер тавыш барлыкка китерү. *Әт исә, аларның шау-шуына карамыйча, кружкадагы сыраны лачкылдатуында булды.* Ш. Еникеев.

ЛАЧКЫЛДАУ *ф. сөйл.* Пычрактан яки баткактан барганда үзенә бер махсус тавыш чыгару. *Лачкылдап бару.*

Лачкылдап тору — камыр ашының чи булуы турында. *Ипи лачкылдап тора.*

ЛАЧ-ЛАЧ *аваз изәр. к.* лач-лоч. *Булдык палач, Чәйнәп сагызлар лач та лач.* Г. Тукай.

ЛАЧ-ЛОЧ *аваз изәр.* 1. Пычрактан яки баткактан атлап барганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Аның пычракны бертуктаусыз лач-лоч изеп барган нәни аяклары арыдылар.* Г. Гобәй.

2. Берәр нәрсәне ялаганда, чәйнәгәндә яки эчкәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. *Бу бәндәнең ниндидер бер тылгысыз комсызлык белән чиләккә май тутырганда лач-лоч бармагын ялавы --- Зиннәтнең канын кыздыра.* Г. Бәширов. *Песи лач-лоч итеп ялый, рәхәтләнде каймакка.* Д. Аппакова.

ЛАЧМА *рәв. сөйл. к.* лычма. [*Мисбах*] *кулын сузып әледән-әле аякларын капшап ала: итек эчләре лачма кан!* Г. Әпсәләмов.

ЛАЧТ *аваз изәр. к.* лач I. [*Әхтәм*] *лачт итеп Госманга таба төкерде.* Г. Ибраһимов.

ЛАЧТЫР-ЛОЧТЫР *аваз изәр. к.* лаштыр-лоштыр.

ЛАЧЫН *и.* 1. Бик үткен томшыклы, һавада озын канатларын җәеп, аны какмыйча да оча ала торган зур ерткыч кош. *Ау лачыны.* □ *Кыю һәм горур җәелә колачын. Зәңгәр киңлектә оча яшь лачын.* З. Мансур.

2. *күч. юг.* Батыр, кыю ир-егет турында. — *Орденнарын күрдеңме? --- Икәү, ике орден. Лачын ул.* Г. Гобәй. [*Тәһир:*] *Бөркетебезнең язмышы авыр, егетләр!* [*Надерша:*] *Бөркетне коткара алырлык лачыннар күп.* И. Туктар. || *с. мәгъ. юг.* Батыр, кыю, үткен. *Ул күрсәтте миңа яшь егетне; бөдрә чәчле, лачын карашлы.* Ш. Маннур.

3. *күч. юг.* Совет летчиклары һәм самолетлары турында. *Корыч канатлы яшь лачын Сыкратты фрицларны, Каныкты безнең лачынга Кипкән йөзле, бүре күзле Дошман зенитчиклары.* Ф. Кәрим.

Лачын сөте — аракы. *Түрәләр белән сөйләшкәндә батыррак булу өчен лачын сөтен дә оныта.* Ә. Айдар.

ЛАЧЫНЧАЛАР *и. зоол.* Лачын, кобчик кебек ерткыч кошлар кергән семьялыкның атамасы.

ЛАШ *аваз. изәр. к.* лышк. *Миңзифа лаш итеп борынын тартты.* М. Әмир.

ЛАШБЫК *с. диал.* Җәенке, җәлпәк. *Лашбык борын.*

ЛАШМАН *и. иск. сөйл.* 1. *к.* лашманчылык.— *Үткән көз мин лашманда казна хезмәтендә йөргән вакытта, имана түләргә юне булмаганга, минем хатынның актык кәҗәсен саттыргансыз.* М. Гали. *Кәрим авылда булмаган, аны лашманга озаткан булганнар.* Г. Әпсәләмов.

2. *к.* лашманчы (1 мәгъ.). *Ясаклы татарлар белән берәттән, лашманнар җан башыннан налог та, башка күп төрле салымнар да түләгәннәр, рекрут биргәннәр.* Каз утл.

3. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында тылдагы хезмәтне үтәр өчен Төркстанның җирле халкыннан җыелган гаскәр.

Лашман тарту (куу, кисү) — лашманда урман кисү, лашманда эшләү. [*Галәк бабай:*] *Петр патша [кораблар] ясаткан, шуңа бөтен ил белән урман кискәннәр. Безнең бабайлар мари урманнарында лашман куганнар.* Г. Әпсәләмов. — *Синең туганнарың лашман тарта.* М. Фәйзи.

ЛАШМАНЧЫ *и. иск.* 1. Лашманчылыкта эшләүче, лашман хезмәтендә эшләүче. *Кара Ширмә буенда үрдәк йөрер тезелеп, Лашманчылар кайтканнан соң, әнкәм йөрер тилмереп.* Бәет. *Лашманчылар күп мәртәбәләр баш күтәрәләр.* Каз утл.

2. Лашман (3 мәгъ.) гаскәрендә хезмәт итүче, хезмәт армиясе солдаты. [*Фазыйл*] *авылга күренмәде, шунда каралып алынганмы, ничектер, Мәскәүгә барганда лашманчыларга башлык сыман булып урынга кергән.* Г. Ибраһимов. *Империалистлар сугышы вакытында Төркстанның җирле халыкларыннан лашманчылар алынып, фронтларга окоп казырга озатыла башлагач, --- [бу парчалар] язылган иде.* М. Гафури.

ЛАШМАНЧЫЛЫК *и. иск.* Революциягә кадәр: солдат хезмәтеннән һәм төрле эш йөкләмәләреннән азат ителгән дәүләт крестьяннарының, үз якларыннан китеп, корабльләр төзү өчен урманда агач әзерләве. *Лашманчылык халыкка гаять авыр йөк булып төшә.* Х. Ярми.

ЛАШПЫРДАУ *ф. сөйл. к.* лапшырдау.

Лашпырдап тору — *к.* лапшырдап тору. *Бишмәт лашпырдап тора.*

ЛАШТЫРДАТУ *ф.* Аяк киеме юеш яки зур булганлыктан, өстерәп йөргәндә үзенә бертөрле тавыш чыгару. *Галошларны лаштырдатып бару.*

ЛАШТЫРДАУ *ф.* Аяк киеменең юеш булуы яки зур булып өстерәлүе сәбәпле, йөргәндә үзенә бертөрле тавыш барлыкка килү. *Минем оек-чабатам эштән чыгып пычранган, су тулып, лаштырдап тора.* Г. Ибраһимов.

ЛАШТЫР-ЛАШТЫР *аваз иәр. к.* лаштыр-лоштыр.

ЛАШТЫР-ЛОШТЫР *аваз иәр.* Аяк киеме юеш яки зур булу сәбәпле, юеш юлдан барганда, йөргәндә һ. б. ш. вакытларда чыккан тавышны белдерә. *Дәү киез итеге белән лаштыр-лоштыр салам ерып, өстенә сары тун, башына бүрек кигән Шәмсетдин килеп чыкты.* Г. Бәширов. *Чана бозылып беткән йомшак язгы юл өстеннән лаштыр-лоштыр сөйрәлә.* М. Әмир.

Лаштыр-лоштыр килү — шундый тавыш чыгару. *Галошлар лаштыр-лоштыр килү.*

ЛА'ЯКЫЛ *рәв.* Бик нык, бөтенләй (исерү турында). *Беркөн төнлә Вафа лаякыл исереп кайтты һәм мәдрәсә буйлап сүгенеп йөрде.* Ә. Фәйзи.

ЛАҖЫРАЮ *ф. диал.* Җәелү; җәелеп утыру яки җәелеп яту. *Юл уртасында ук лажыраеп яткан казлар, муеннарын сузып, читкәрәк тайпылырга мәҗбүр булдылар.* Р. Төхфәтуллин.

ЛАҢГЫРТ *аваз иәр.* Берәр әйбер югарыдан килеп төшкәндә яки ауганда барлыкка килгән үзенә бертөрле тавышны белдерә. *Самовар лаңгырт итеп килеп төште.*

ЛЕБЁДКА *и.* Йөкләрне күтәрү һәм бер урыннан икенче урынга күчерү өчен махсус җайланма; чыгыр.

ЛЕБЕРДӘҮ *ф.* Бер-беренә җиңелчә генә бәрелеп, үзенә бертөрле тавыш барлыкка китерү, лебер-лебер килү (күбрәк агач яфраклары турында). *Хатын-кыз күңеле усак яфрагы кебек лебердәп 'тора.* Әйтем.

ЛЕБЕР-ЛЕБЕР *аваз иәр.* Үсеп утырган агач яфраклары бер-беренә җиңелчә генә бәрелгәндә һәм башка кайбер хәрәкәтләр вакытында барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лебер-лебер килү — *к.* лебердәү. *Усак яфраклары лебер-лебер килә.* □ *Күреп үттек каен чукларының Лебер-лебер килеп уйнавын.* Ш. Маннур.

ЛЕВ *и.* Болгария Халык Республикасында акча берәмлеге.

ЛЕВИАФАН *и. дини.* Тәүрат риваятендә: диңгездә яки күктә яшәүче бик зур ерткыч хайван, коточкыч зур мифик зат.

ЛЕВИРАТ *и. этн.* Кайбер Көнчыгыш халыкларында һәм еврейләрдә: баласыз тол хатынны үз каенесенә кияүгә чыгарга мәҗбүр итә торган патриархаль гадәт, йола.

ЛЕВКАС *и махс.* Агач әйберләрнең өслеген буяр алдыннан тигезли торган җилем белән алебастр яки акбур катнашмасы; шул катнашма сыланган агач әйберләр өстендәге җирлек.

ЛЕВКОЙ *и.* Әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан төрле төстәге хуш исле чәчәкле бакча гөле; *к.* шеббуй. *Ландышлар да, левкойлар да, Яушаннар да күп үсә.* Ә. Ерикәй.

ЛЕВРЕ'ТКА *и.* Бурзай токымыннан булган бүлмә эте.

ЛЕГАЛЬ *с.* Закон рөхсәт иткән, рәсми рөхсәт ителгән; ачык эшчәнлек алып бара торган. *Легаль партия. Легаль матбугат.* □ *Патша хөкүмәте социал-демократларның легаль органы „Правда" газетасын чыгарырга рөхсәт бирергә мәҗбүр була.* Г. Нигъмәти. || Закон тәртибендә эш итүгә нигезләнгән, рәсми мөмкинлекләрдән файдалана торган яки файдалануга корылган. *Большевиклар, легаль булмаган партия оешмасы җитәкчелегендә, легаль булмаган эшне легаль эш белән бергә кушарга өйрәнергә тиешләр иде.* КПСС тарихы.

Легаль марксизм — XIX гасырның 90 нчы елларында рус интеллигенциясе арасындагы үзенең бурҗуаз либерализмын марксистик положениеләр белән яшерергә тырыша һәм марксизмны бозып аңлата торган агым. **Легаль марксист** — легаль марксизм яклы кеше, легаль марксизм тарафдары. *„Легаль марксистлар" буржуаз идеологияне гәүдәләндерүчеләр булдылар.* КПСС тарихы.

ЛЕГАЛЬЛЕК *и.* Легаль булу. *Матбугатның легальлеге.*

ЛЕГАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Легаль хәлгә күчерү, легаль итү. [*Батырхан:*] *Менә шунда сезне легальләштерү турында да уйлашып карарбыз.* К. Тинчурин.

ЛЕГАЛЬЛӘШҮ *ф.* Легаль хәлгә күчү.

ЛЕГАТ *и.* 1. *иск.* Борынгы Римда аерым провинцияләрдәге дәүләт хезмәте кешесе.

2. Рим папасының дипломатик вәкиле.

ЛЕГА'ТО *рәв. муз.* Бер аваздан икенче авазга күчкәндә өзмичә һәм салмак итеп (музыкаль әсәрләрне башкару).

ЛЕГАШ *и.* Кош яки җәнлек аулаганда аны исеннән эзләп барып таба торган ау эте.

ЛЕГГОРН *и.* Йомырка күп сала торган, күбесенчә ак төстәге тавык токымы. *Ак рус тавыклары леггорн тавыкларыннан китереп чыгарылды.* Зоология. *Леггорн токымыннан булган тавыклар 4—6 айлык вакытта --- йомырка сала башлыйлар.* Йорт эшләре.

ЛЕГЕ'НДА *и.* 1. Тарихи вакыйгалар яки аерым шәхесләр турында борынгыдан калган шигъри риваять яисә фантастик хикәя. *Казакъ, башкортлар арасында толпар турында бик күп легендалар бар.* М. Гафури. *„Алтынчәч" халык легендасын әкият фонында күрсәтергә тиеш.* М. Җәлил. || Дини фантастик риваять. *Дини легенда сюжетында, ләкин аңа пародия рәвешендә язылган „Яңа кисекбаш" поэма-*

сы, --- „Алтын әтәч", „Кәҗә белән сарык әкияте" [уйдырма һәм әкиятләрдән файдаланып язылган әсәрләргә] керәләр. Г. Нигъмәти.

2. *махс.* Планга, картага һ. б. ш. карата бирелгән аңлатма язуы һәм шартлы билгеләр.

3. *махс.* Медальгә, металл акчага һ. б. ш. төшерелгән язу.

ЛЕГЕНДАР *с.* 1. Үзенең гадәттән тыш яклары белән (мәсәлән, батырлыгы белән) легендаларга кергән, аеруча зур батырлыклар күрсәткән; тиңе булмаган. *Легендар Чапаев.* □ *Ерак төньякның каракъгы таш кыялары өстендә басып торган сакчылар, Белоруссия сазлыкларында радиоалгыч тирәсендә җыелган легендар партизаннар — бөтенесе күз алдыннан узды.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Чын булмаган, чынга охшамаган, хыялый. *Нинди генә хыялый, легендар сурәтләрдә бирелгән әсәр булмасын, без [аларны] тикшерергә, бәя бирергә тиешбез.* Г. Нигъмәти.

ЛЕГИОН *и.* 1. *иск.* Борынгы Римда әре гаскәри подразделение. *Рим гаскәре легионнарга бүленгән, аларның һәрберсендә 4500 сугышчы булган.* Бор. зам. тарихы.

2. Төрле чордагы төрле хәрби частьларның исеме. *Легионда барлыгы бер мең ике йөз кеше.* Ш. Усманов.

ЛЕГИОНЕР *и.* Легионга кергән сугышчы, легион солдаты. *Цезарь легионерлары.*

ЛЕГИРЛАУ *ф.* Төп металлга, аның үзлекләрен яхшырту өчен, башка металлар кушып эретү.

ЛЕГИРЛАШТЫРУ *ф. к.* легирлау. *Шихтаның составын бик нык үзгәртергә һәм күп төрле составтагы — углеродлы корыч та, легирлаштырылган корыч та җитештерергә мөмкин.* Химия.

ЛЕГИСЛАТУ'РА *и. махс.* 1. Буржуаз илләрдә: закон чыгара торган органнарның эшчәнлек чоры, вәкаләт срогы.

2. Кайбер илләрдә (мәсәлән, Англиядә) закон чыгара торган органнар (барысы бергә).

ЛЕГИТИМА'ЦИЯ *и. махс.* 1. Кемнең дә булса берәр төрле хокукын яки вәкаләтен тану яисә раслау.

2. Шул хокукны яки вәкаләтне раслый торган документ.

3. Буржуаз хокукта никахсыз туган балаларны законлаштыру, аларга законлы балалар хокукын бирү.

ЛЕГИТИМИЗМ *и. махс.* XIX — XX йөзләрдә Көнбатыш Европада (бигрәк тә Франциядә): дәүләттә бер нәселдән килгән монархлар гына властька хокуклы дигән принципны яклый торган политик агым.

ЛЕГИТИМИСТ *и. махс.* Легитимизмны яклаучы кеше, легитимизм тарафдары.

ЛЕДЕРИН *и.* Үзенә бер махсус матдә (лак) сеңдерелгән мамык тукымадан гыйбарәт ясалма күн (китап тышлыгы өчен кулланыла). *Ледерин тышлык белән чыгарылган бу китапта шагыйрьнең фоторәсеме дә бирелгән.* Каз. утл.

ЛЕ'ДИ *и.* Англиядә лорд яки баронет хатыны. || Инглиз телендә сөйләшкән илләрдә кияүдәге хатынны ихтирам йөзеннән шулай атыйлар.

ЛЕ'ЕР *и. махс.* Ике очы ике якка беркетелеп, бик нык тарттырып куелган трос (корабларда ябышып йөрү өчен).

ЛЕ'ЗВИЕ *и.* Ике ягы да үткен бик юка корыч пластинка, кырыну приборының бер кисәге. — *Үзең белән инә, җеп, лезвиелар --- алып кил.* М. Җәлил.

ЛЕЗГИН *и.* Дагстанда һәм Азербайҗан ССРның төньягында яшәүче бер халык атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. || *с. мәгъ.* Шул халыкка, аның культурасына бәйләнешле. *Лезгин теле.*

ЛЕЗГИ'НКА *и.* 1. Лезгин хатын-кызы.

2. Кызу темпта башкарыла торган кавказ биюе.

ЛЕЗГИ'НЧА *рәв.* Лезгин телендә; лезгин телендә язылган. *Лезгинча сөйләшү.*

ЛЕЙБ-ГВА'РДИЯ *и.* Башында монарх торган кайбер дәүләтләрдә: үзенә аерым өстен хокуклары булган гаскәр (элек патшаның тән сакчыларын шулай атаганнар). *Лейб-гвардия офицеры.* □ *Җаек казакларыннан төзелгән махсус казачий лейб-гвардия саклый патша сараен.* М. Фәйзи.

ЛЕЙБ-МЕ'ДИК *и.* Патша сарае врачы.

ЛЕЙБОРИСТ *и.* Политикада реформачылык юлын яклаучы Англия эшчеләр партиясе члены. *Лейбористлар съезды.* □ *Лейбористлар, без капиталистик җәмгыятьне революцион юл белән үзгәртмичә генә „демократик социализм" төзергә телибез, --- дип белдерәләр.* Иң яңа тарих.

ЛЕ'ЙДЕН: лейден банкасы *физ.* — электр туплау өчен иң гади прибор. *Конденсаторларның иң иске тибы булган лейден банкасын һәрбер мәктәпнең физика кабинетында очратырга мөмкин.* Физика.

ЛЕ'ЙКА I *и.* 1. Үсемлекләргә су сибү өчен махсус сиптергече булган чиләк, су сипкеч. [*Конрад*], *кулына лейка тотып, фонтан янына килеп туктады.* Н. Дәүли. *Карасам, җирдә бакчадагы гөлләргә су сибә торган лейка ята.* С. Рахманколый.

2. *махс.* Суны чумырып, сосып алып түгү өчен зур чүмечкә охшаган савыт. [*Хөснетдин*] *озын саплы лейка белән чалтырата-чалтырата былтырдан калып сасыган селёдка суын ушатка тутыра башлады.* Ш. Камал.

ЛЕ'ЙКА II *и.* Тар плёнкалы кечерәк фотоаппарат. [*Катя:*] *Бирдә лаборатория юк, лейканың аның мәшәкате күп.* И. Гази.

ЛЕЙКЕМИ'Я *и. мед.* Канда ак кан тәнчекләренең бик нык артып китүе аркасында килеп чыга торган авыру, акканлылык.

ЛЕЙКОЦИТОЗ *и. мед.* Канда ак кан тәнчекләренең вакытлыча күбәеп китүе.

ЛЕЙКОЦИТ *и. мед.* Канның состав кисәген тәшкил иткән ак кан тәнчеге.

ЛЕЙТЕНАНТ *и.* Армиядә һәм флотта кече лейтенант дәрәҗәсеннән югарырак офицер дәрәҗәсе, чины; шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Лейтенант Иванов ротасы урман эче буйлап зур саклык белән алгы позициягә таба бара.* Ә. Еники. *Анда Гайсин фамилияле бер лейтенантның, үзе команда биреп, үз өстенә орудиедән аттыруы язылган иде.* Г. Бәширов.

ЛЕЙТМОТИВ *и.* 1. *махс.* Музыка әсәренең буеннан-буена кабатланып килгән төп мотив, төп тема. *Музыкада Булатның темасы дәртле, ышанычлы яңгырый. Аның көрәшкә чакырып, өметне өзмәскә өндәгән юллары бөтен әсәр буенча лейтмотив булып баралар.* М. Җәлил.

2. *күч.* Кабатлый-кабатлый ассызыклап, басым ясап күрсәтелгән фикер. *Поэманың лейтмотивы.* □ *Гражданнар сугышы чорындагы революцион татар әдәбиятының төп идея лейтмотивы яшь Совет республикасының эчке һәм тышкы дошманнарына каршы көрәшкә чакырудан --- гыйбарәт булды.* Г. Халит.

ЛЕКА'ЛО *и.* 1. Кәкре сызыклар сызу өчен фигуралы линейка. *Лекалолардан файдаланып, гиперболаның графигын төгәлрәк итеп сызарга мөмкин.* Алгебра.

2. *иск.* Детальләрнең туры булмаган контурларын тикшерү инструментының иске атамасы; калибр.

ЛЕКА'ЛЬЩИК *и.* Лекало (2 мәгъ.) ясаучы эшче.

ЛЕ'КАРЬ *и. иск., сөйл.* Врач (революциягә кадәр врачка бирелгән рәсми исем).

ЛЕКПОМ *и. сөйл.* Лекарь ярдәмчесе, фельдшер. *Бүлмәгә баш врач белән бергә дежурный врач, дежурный лекпом һәм кара бөдрә чәчле, карасу күзле бер сестра килеп керде.* А. Шамов.

ЛЕКСЕ'МА *и. лингв.* Үзенең барлык формалары һәм мәгънәләре белән мөстәкыйль әйтәлекле берәмлек буларак сүз.

ЛЕ'КСИК *с.* Лексикага караган, лексикага бәйләнешле. *Татар теленең лексик байлыгы.*

ЛЕ'КСИКА *и.* Нинди дә булса бер телдәге яки диалекттагы барлык сүзләр. *Татар теленең лексикасы. Көнбатыш диалект лексикасы.* || Нинди дә булса әшчәнлектә, аның берәр тармагында кулланыла торган барлык сүзләр. *Профессиональ лексика.* || Нинди дә булса язучының телендә кулланылган сүзләр составы. *Тукай лексикасы.*

ЛЕКСИКО'ГРАФ *и.* Лексикография белгече, сүзлекләр төзүче һәм аның принципларын тикшерүче белгеч.

ЛЕКСИКОГРА'ФИК *с.* Лексикографиягә караган, лексикографиягә бәйләнешле, сүзлекләр төзү эшенә караган. *Лексикографик эзләнүләр.* □ *Дәтелгән чорда [XIX йөздә] чыккан китаплар арасында университет басмасы яки авторлар үзләре бастырган --- лексикографик һәм әдәби әсәрләр дә бар.* И. Рәмиев.

ЛЕКСИКОГРА'ФИЯ *и.* 1. Сүзлекләрне төзү эше, сүзлек эше. *Татар лексикография тарихы.*

2. Тел белеменең сүзлекләрне төзү теориясен тикшерә торган бер тармагы, дисциплинасы. *Лексикографиягә багышланган тикшеренү.*

ЛЕКСИКО'ЛОГ *и.* Лексикология белгече, лексиканы өйрәнүче белгеч.

ЛЕКСИКОЛО'ГИК *с.* Лексикологиягә караган, лексикологиягә бәйләнешле. *Лексикологик тикшеренү.*

ЛЕКСИКОЛО'ГИЯ *и.* Тел белеменең лексиканы тикшерә торган бер тармагы, дисциплинасы. *Татар теленең лексикологиясе.* □ *Лексикология тел белеменең башка тармаклары белән тыгыз мөнәсәбәттә тора.* Хәз. тат. әд. теле.

ЛЕ'КТОР *и.* Лекцияләр сөйләүче. *Лекторлар группасы.* □ [*Җаббаров*] *лектор булып йөрде. Инструктор да булды. Контроль комиссиясендә дә зур эшләр башкарды.* М. Әмир.

ЛЕКТО'РИЙ *и.* Халыкка лекцияләр сөйләүне оештыру эше белән шөгыльләнә торган учреждение; лекцияләр сөйләү өчен билгеләнгән бина.

ЛЕ'КТОРЛЫК *и.* Лектор булу, лектор булып эшләү.

ЛЕ'КЦИЯ *и.* 1. Югары уку йортларында укытучының үзе укыткан фәнне, предметны телдән сөйләве. *Шакир барганда, университетта лекцияләр укылып бетеп, халык инде тарала да башлаган иде.* Ф. Әмирхан. *Рус әдәбияты буенча кергән укытучы Морозов та беренче лекциясен шул фикерләр белән башлады* Г. Кутуй. || Югары уку йортында укытучының шундый сөйләвеннән гыйбарәт уку дәресе. *Лекцияләргә йөрү.* □ [*Разия:*] *Профессор Демидов --- шалтыраткан, институтта лекцияләрем беткәч тә киләм, дигән.* Р. Ишморат. || Нинди дә булса темага халык алдында чыгып сөйләү, чыгыш ясау. *Көннәрдә беркөн иптәшемә: „Мин халык әдәбияты турысында лекция укыйм“, — дип әйткән идем.* Г. Тукай. *Большевиклар оештырган җыелышларга, лекцияләргә еш йөрде ул.* И. Гази.

2. *күбрәк күпл.* Югары уку йортларында нинди дә булса фән, предмет буенча укыла торган яки укылган текстларның язылган яки басылган язмасы, конспекты. *Типографиядә басылган лекцияләр.* || Халык алдына чыгып сөйләнә торган яки сөйләнгән чыгышның язылган яки басылган язмасы, конспекты.

◇ **Лекция уку** — үгет-нәсихәт бирү, мораль уку. *Тәмәкене ташларга Кушалар врачлар да. Лекция укый хатын да Шул тәмәке хакында.* Б. Рәхмәт. [*Мостафа:*] *Ул синең үзе турында „бәндә“ дигән сүзеңне ишетеп алган. Миңа шул турыда бик әйбәт лекция укыды.* Ш. Камал.

ЛЕ'ММА *и. мат.* Башка бер теореманы яки теоремаларны исбатлау өчен кирәк булган ярдәмче теорема.

ЛЕ'ММИНГ *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан чуар, көрән-сары төстәге озын йонлы кечкенә хайван, төньяк йомраны.

ЛЕМУР *и.* 1. Борынгы Рим мифологиясендә: үлгән кешенең җаны, өрәк.

2. *зоол.* Маймыл белән аңардан түбәнрәк имезүче хайваннар арасында торган хайван, ярым маймыл (Африкада, Азиянең көньяк-көнчыгыш өлешендә яши).

ЛЕН *и. тар.* 1. Урта гасырларда: эре феодал тарафыннан үзенең вассалына хәрби хезмәте өчен бирелгән, нәселдән күчә килгән биләмә; шундый җирне биләү хокукы.

2. Шундый биләмәләрдән җыеп алына торган имана.

ЛЕНД-ЛИЗ *и.* Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Америка Кушма Штатларының союздаш илләргә бурычка яки арендага кораллар, стратегик чимал, азык-төлек һ. б. ш. бирү системасы. *Ленд-лиз буенча Советлар Союзына җибәрелгән ярдәм Англиягә җибәрелгән ярдәмнән өч тапкыр кимрәк булды.* Иң яңа тарих.

ЛЕНДЛОРД *и.* Англиядә: җирен фермерларга арендага бирүче эре җир биләүче, алпавыт. *Ленд-лордларга рента түләү.*

ЛЕНИНИА'НА *и.* Бөек юлбашчы В. И. Ленинның тормышы, эшчәнлеге һәм образы турындагы барлык әсәрләр һәм документлар.

ЛЕНИНИЗМ *и.* Пролетар революцияләр һәм империализм шартларында марксизмны алга таба үстерүдән гыйбарәт булган В. И. Ленин тәгълиматы. *Ленинизмны өйрәник, Иске тормыш җиңелсен.* Җыр. *Ленинизм җиңә һәр фронтта.* Ф. Бурнаш.

ЛЕ'НИНЧА *рәв.* В. И. Ленин тәгълиматына, ленинизм принципларына туры китереп. [*Яшь большевик:*] *„Тик Ленинча, большевикча“, — диде.* М. Җәлил.

ЛЕ'НИНЧЫ *и.* Ленинизм тарафдары, ленинизм яклы кеше. *Ленинчылар монолит һәм сугышчан, аныk оешкан --- партия ягында булдылар.* КПСС тарихы. *Комсомоллар—яшь ленинчылар алар, Комсомоллар — искелеккә Бомбалар!* Һ. Такташ.

ЛЕ'НИНЧЫЛ *с.* Ленинизм принципларына туры килгән, ленинизмны яклаган. *Ленинчыл милли политика.* □ *Изелгән милләтләрнең хезмәт иясе массалары рус пролетариатына ышаныч белән карасыннар --- өчен ленинчыл „Искра“ күп эшләде.* КПСС тарихы. || Ленинизм яклы булган, В. И. Ленин тәгълиматы яклы булган. *Һәр көрәштә алгы сафта Син, ленинчыл комсомол.* Җыр.

ЛЕ'ННИК *и. тар.* Лен хуҗасы, эре феодалдан лен алган вассал.

ЛЕ'НТА *и.* 1. *сөйл. к.* тасма. *Чәчен зәңгәр лента белән кушып үргән, маңгае ап-ак, күзләре түгелергә торган төсле.* Ф. Хөсни. || Берәр нәрсә билгесе итеп баш киеменә, күкрәккә тагылган яки беләккә бәйләнгән төсле тукыма кисәге. [*Полковник*] *янында, гаскәриләрдән --- башка, солдатларныкына караганда киңрәк итеп яшел ленталар аскан биш-алты унтер күренә.* Ш. Камал. *Аның башында Костин-*

ныкы шикелле бүрек, бүрегендә Костинныкы шикелле кызыл лента булсын иде. Г. Гобәй.

2. Нинди дә булса материалдан ясалган, техник яки башка максатлар өчен хезмәт итә торган озын тар буй. *Телеграф лентасы. Изоляция лентасы.* || Киноплёнка, кинолента. *Тарзан. Джунгли маймыллары. --- Чү! Кинәт лента өзелде.* Һ. Такташ.

3. Кайбер транспорт җайланмаларының, механизмнарның төп өлешен тәшкил итә һәм әйләнеп тора торган полотно, киң калын тасма. *Конвейер лентасы.* □ *Бер зур машинаның лентасы әйләнеп тора.* А. Алиш. || Патроннар өчен оясы булган тасма. *Өметбаев лентага патрон тезеп утырган җиренән башын пулеметына куеп йокыга киткән.* Г. Гобәй.

ЛЕНЧ *и.* Англиядә һәм АКШта: төштән соң әзерләнгән икенче аш табыны; көннең теләсә нинди башка вакытында ашау өчен әзерләнгән нинди дә булса җиңелчә ашамлык, аш.

ЛЕП: леп итеп — кинәт, кисәктән, капыл. *Әмиржан шулай дигәч, моннан бер ай чамасы элек Григорийның сөйләгән сүзләре леп итеп Садыйк хажиның исенә төште.* Ш. Камал.

ЛЕПЕЛДӘҮ *ф. сөйл.* 1. Көчле рәвештә йөрәк яки кан тамыры тибү. *Бабайның куркуы артып, йөрәге лепелди башлады.* Шура.

2. *к.* лепердәү. *Яфраклар акрын гына лепелдәшәләр.* Р. Төхфәтуллин.

ЛЕПЕРДӘҮ *ф. сөйл. к.* лепер-лепер килү. *Аланнарга килеп чыкканда, усак яфраклары, куанышып кул чапкандай, аны лепердәшеп каршы алалар.* Г. Бәширов. *Әкрен җилгә лепердиләр сазда мүкләр.* Ә. Ерикәй.

ЛЕПЕР-ЛЕПЕР *авазияр.* Агач яфраклары, кайбер үсемлекләр һ. б. ш. җилдә селкенеп, бер-беренә бәрелгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лепер-лепер килү (итү) — шундый тавыш, авазлар барлыкка китерү (агач яфраклары, үсемлекләр һ. б. ш. җилдә селкенгәндә).

ЛЕПКӘ *и.* Башның түбәсендә маңгай, баш чүмече һәм чигә сөякләре тоташкан урын; башның түбәдән маңгайга кадәр булган өлеше. [*Җаббаровның*] *шактый сирәкләнеп калган чәчләре үтәли соргылт лепкәсе күренә.* М. Әмир.

ЛЕП-ЛЕП *обр.ияр.* 1. Йөрәк яки кан тамыры тибүне белдерә. *Ничек түзсен йөрәк леп-леп тибеп!* Б. Рәхмәт.

2. Күбәләк очканда, күз кабакларын еш-еш йомып ачканда һ. б. ш. вакытлардагы хәрәкәтне белдерә. *Йокы авырайткан керфекләрен күтәрә алмаган күз кабаклары леп-леп йомыла торгач,* [*ул*] *кырын авып йоклап та китте.* Г. Минский.

Леп-леп итү (килү) — 1) йөрәк яки кан тамыры тибү турында. *Алдым кулыма чиләгем, Леп-леп итәдер йөрәгем.* Җыр; 2) күбәләк очканда, күз кабакларын еш-еш йомып ачканда һ. б. ш. вакыттагы хәрәкәт-тавышны белдерә. *Леп-леп итеп оча күбәләкләр, Чутылдашып сайрый кошлары.* М. Гафури.

ЛЕ'ПРА *и. мед.* Махау авыруы; *русчасы:* проказа.

ЛЕПРОЗО'РИЙ *и.* Махау авыруы белән авырган кешеләр өчен дәвалану учреждениесе, проказалы авырулар колониясе.

ЛЕРТ-ЛЕРТ *обр.ияр.* Вак адымнар белән салмак кына йөгереп яки юыртып баруны белдерә. *Лерт-лерт йөгерү.* □ *Лерт-лерт итеп юырткан үшән атка гына утырып йөрүгә ризалашмаса да, кая барсын.* А. Гыйләҗев.

ЛЕСНИК *и. сөйл.* Урман каравылчысы.

ЛЕСНИ'ЧЕСТВО *и.* Хуҗалык берәмлеге буларак билгеле бер урман участогы, шундый участок белән җитәкчелек итә торган идарә (лесхозның бер бүлекчәсе).

ЛЕСНИ'ЧИЙ *и.* Лесничествоның мөдире, җитәкчесе. [*Даниил агай:*] *Лесничийдан кайтып киләм. Шәһәр хәлләрен сорашырга барган идем.* К. Тинчурин.

ЛЕСОВОЗ *и.* Агач материалларын ташу өчен транспорт (судно яки автомашина).

ЛЕСПРОМХОЗ *и.* Билгеле бер территориядә агач әзерләү, аны эшкәртү һәм читкә озату белән шөгыльләнә торган дәүләт предприятиесе. *Леспромхозда Газинурны барыннан да элек коллектив эшнең колачы, бердәмлеге, урман кисүчеләрнең бер җан, бер тән булып эшләүләре --- сокландыра иде.* Г. Әпсәләмов.

ЛЁСС *и. махс.* Туфрак барлыкка китерә торган ачык сары төстәге көпшәк тау токымы. *Лёсс утырмалары бик йомшак һәм күп карбонатлы, катлаусыз бер токым булып санала.* А. Фаткуллин.

ЛЕСХОЗ *и.* Урман үстерү һәм агач әзерләү белән шөгыльләнә торган урман хуҗалыгы, урман совхозы.

ЛЕТАРГИК *с.* Летаргиядән гыйбарәт, летаргия булган. [*Авыру*] *врачлар летаргик йокы --- дип атый торган халәткә күчкән.* Сер пәрдәсен ачсак...

ЛЕТАРГИ'Я *и.* Авыр очракларында сулыш алу һәм пульс сизелмәслек дәрәҗәдә булып, организм тышкы реакцияләргә җавап бирми торган, озак йокыга охшаган авыру халәте; мәрт.

ЛЕ'ТКА-Е'НКА *и.* Күңелле күмәк бию; танец (Финляндиядә иҗат ителгән).

ЛЁТКА *и. махс.* Домна мичләрендә металл яки шлак чыгара торган тишек. *Горнда шлак һәм чуен җыелуга, аны мичтән лёткалар аркылы чыгаралар.* Химия.

ЛЕТУН *и. сөйл.* Эш урынын еш алыштыручы кеше (гадәттә акча артыннан куып). [*Гөләндәм:*] *Летун түгел лә мин качарга.* К. Тинчурин. | *с. мәгъ.* — *Ялкау, летун егетләргә Кыз кияүгә бармасын.* Г. Камал.

ЛЕТУ'ЧКА *и. сөйл.* 1. Бик ашыгыч мәсьәләләрне хәл итү өчен кыска вакытта үткәрелә торган киңәшмә.

2. Бер урыннан икенче урынга бик тиз генә йөри торган, махсус җиһазландырылган ремонт машинасы. *МТС летучкасы.*

3. Спектакль куелу, концерт бирелү һ. б. ш. турында кәгазьгә басылып халыкка таратыла торган ашыгыч игълан, кечкенә афиша. *Афишалар ябыштырдык. Летучкалар тараттык, билет саттык.* Г. Хәсәнов.

ЛЁТЧИК *и. сөйл. к.* очучы. *Лётчик үзе дә, кулларын штурвалдан җибәрмичә генә, әледән-әле пыяла ишек аша пассажирлар ягына карап ала.* Г. Гобәй.

ЛЕШПЕРДӘҮ *ф. сөйл. к.* лепердәү. *Баш очында яфрак лешпердәвен тыңлап, шулай икәүдән-икәү утыру бик рәхәт була аңа.* И. Гази.

ЛЕ'Я I *и.* Румыниядә төп акча берәмлеге, шул берәмлек кыйммәтендәге тәнкә, акча билгесе.

ЛЕ'Я II *и.* Кавалерист чалбарының атка атлангач ияргә тиеп торган урынына тегелгән күн яки башка шундый нык материал.

ЛИ *и.* 1. Кытайда 576 метрга тигез булган озынлык үлчәү берәмлеге.

2. Монголиядә, Вьетнамда, Кытайда алтын һәм көмеш үлчәү берәмлеге — 37 миллиграммга тигез.

ЛИА'НА *и.* Күбрәк тропик һәм субтропик урманнарда таралган, үрелеп яки уралып үсә торган үлән һәм агач сыман үсемлекләрнең атамасы.

ЛИБЕРАЛ *и.* 1. Либерализм тарафдары, либерализм яклы кеше. *Ишаннан өмет өзгәч, Урманов либераллларга сугылырга уйлап карады.* Г. Ибраһимов.

2. Либераллар партиясе әгъзасы. *Либераллар консерваторлардан (карагруһлардан) шуның белән генә аерылалар ки, алар буржуазия интересларын гәүдәләндерәләр.* В. И. Ленин.

3. *иск.* Хөр фикерле кеше, хөр фикер яклы кеше. [*Әхмәт:*] *Дөрес, мин либерал; яңаның яхшысын кабул итәм, булмаса — юк.* Г. Камал.

4. *күч. сөйл.* Артык килешүчән, юл куючан кеше. *Либерал булырга ярамый.*

ЛИБЕРАЛИЗМ *и.* 1. Буржуаз революцияләр чорында буржуазиянең хокукларын һәм азатлыгын яклый торган, ә буржуазия политик хакимлеккә ирешеп, пролетариатның революцион көрәше үсеп киткән вакытта реакцион агымга әйләнгән политик юнәлеш. *„Искра"ның төп эше либерализмның революциягә дошманлыгын фаш итү булды.* КПСС тарихы.

2. *иск.* Хөр фикерлелек, хөр фикер яклы булу.

3. *күч. сөйл.* Артык килешүчән булу, юл куючанлык. [*Сафаров:*] *Теләсәгез нәрсә әйтегез, иптәшләр, мин моңа либерализм дип карыйм.* Ш. Камал.

ЛИБЕРАЛЛАНУ *ф.* 1. *сөйл.* Килешүчәнлек күрсәтү, юл кую. [*Айрат:*] *Юлдашевны бүген башыннан сыйпасак, нинди нәтиҗәләргә илтәчәген беләсезме сез? Нигә либералланып утырасыз?* Г. Ахунов.

2. *иск.* Либераллык күрсәтү, хөр фикерле булып кылану.

ЛИБЕРАЛЛА'РЧА *рәв.* Либераллларга хас булганча. *Буржуа либераллларча яхшы киенеп, галстук, манжетлар белән ялтырап, сәхнәгә күтәрелгән таза гәүдәле бу иптәшне күргәч, - - - [Солтан] алга таба кысылды.* Г. Ибраһимов.

ЛИБЕРАЛЛАШУ *ф.* Либералга (1, 2, 4) әйләнү, либерал (1, 2, 4) булу.

ЛИБЕРАЛЛЫК *и.* 1. Хөр фикерлелек, хөр фикер яклы булу. | *с. мәгъ. Чехов бервакытта да революционер була алмады, ләкин ул заманның либераллык карашларын (иң яхшы мәгънәсендә алып) үткәрде.* Г. Нигъмәти.

2. *к.* либерализм 3. *Ни өчен, нидән ул Андреев --- либераллык күрсәтте соң?* Ә. Еники. [*Сафаров:*] *Ләкин сизгер мөгамәлә күрсәтәм дип, либераллык дәрәҗәсенә үк барып җитәргә ярамый.* Ш. Камал.

ЛИБЕРАЛЬ *с.* 1. Либерализм (1 мәгъ.) яклы булган, либераллларга (1 мәгъ.) караган. *Либераль партия.* □ *дсәрнең икенче басмасында Казан бае Кәрим белән Уфа бае Сәгыйть образлары нык кына эшләнеп, беренчесе реакцион буржуа, икенчесе либераль буржуа вәкилләре итеп бирелгәннәр.* М. Гали;

2. *иск.* Либераллык (1 мәгъ.) белән сугарылган, либерализм (2 мәгъ.) яклы булган. *Либераль идеяләр.* □ *Либераль карашлы [Арджанов] аның атасы Сигизмундны яхшы белә иде. Икесе дә либераль адвокатлар эчендә кайнадылар.* Г. Ибраһимов.

3. *сөйл.* Килешүчән, юл куючан. *Артык либераль кеше.*

ЛИБЕРАЛЬЛЕК *и. к.* либераллык. *Либераллек күрсәтү.*

ЛИБЕРТИ *и.* Ялтырап торган ефәк яки ярым ефәк йомшак тукыма.

ЛИБРЕТТИСТ *и.* Либретто язучы, либретто авторы. *Либреттистлар хәзерләү.*

ЛИБРЕ'ТТО *и.* 1. Зур музыкаль әсәрнең (опера, оперетта, оратория һ. б. ш.) сүз белән бирелгән тексты. *Опера театры, репертуарда тоткарлык тудырмау өчен, оригиналь либреттолар хәзерләү эшен дәвам иттерә.* М. Җәлил.

2. Кинофильм яки балетның сценарий планы, схемасы.

3. *сөйл.* Башкарыла торган әсәрнең (пьеса, опера һ. б.) гадәттә театр программасында бирелгән кыскача эчтәлеге.

ЛИБРЕ'ТТОЧЫ *и.* Либретто язучы, либретто авторы.

ЛИВА *и. иск.* Байрак. *Тотып милләт ливасын, юлга чыктык: „Бу куллар мәңге, дип, җиргә салынмас".* Г. Тукай.

ЛИВАНЛЫ *и.* Ливанда яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе.

ЛИВР *и.* 1. Французларның соңыннан франк белән алыштырылган борынгы көмеш акчасы.

2. Франциядә чама белән ярты килограммга туры килгән борынгы үлчәү берәмлеге.

ЛИВРЕ'Я *и.* Швейцар, лакей һәм кучерларның гадәттә ука тасма тотылган форма киеме.

ЛИ'ГА I *и.* Иҗтимагый-политик берләшмә, союз (дәүләтләрнең, оешмаларның, төрле катлауларның һ. б.). *Милләтләр лигасы.*

ЛИ'ГА II *и. муз.* Ноталар өстенә дуга рәвешендә куелган билге, ноталарны бер-береннән аермыйча тоташтан уйнарга кирәклекне белдерә.

ЛИГАТУ'РА *и. махс.* 1. Металлга билгеле бер үзлек бирү өчен хезмәт итә торган ярдәмче эретмә. || Алтынга, көмешкә һәм ак алтынга катылык үзлеге бирү өчен кулланыла торган бакыр яки аккургаш кушылмасы.

2. *махс.* Бер язу билгесе белән ике яки берничә хәрефне белдерү (мәсәлән, француз телендәге œ). || *муз.* Югарылыгы ягыннан бердәй булган ике нотаны тоташтыручы, дуга рәвешендәге билге.

3. *мед.* Кан агуны туктату яки кисәтү өчен кан тамырын бәйли торган ефәк җеп.

ЛИГНИН *и.* 1. *биол.* Үзагачта була торган, углеродларга бай матдә. *Лигнин — органик матдә.* А. Фаткуллин.

2. Үзагачтан ясалган, катлы-катлы юка кәгазь рәвешендәге материал, агач мамыгы.

ЛИГНИТ *и. махс.* Түбән сыйфатлы соры күмер.

ЛИГРОИН *и.* Нефтьне куганда барлыкка килә торган продуктларның берсе (ягулык буларак кулланыла).

ЛИ'ДЕР *и.* 1. Берәр политик партиянең, иҗтимагый-политик оешманың һ. б. ш. җитәкчесе, юлбашчысы. *Башкаладагы хәлләр турында кадетлар партиясенең лидерларыннан берсе саналган - - - якын дусы авызыннан ишеткәч, [губернатор] шунда үк округ командующиен чакыртты.* К. Нәҗми.

2. Нинди дә булса ярышта беренче булып баручы кеше яки команда. *Шахмат турнирының лидеры.* □ *Лидерга каршы һәр команда икеләтә көч белән уйный.* Соц. Тат.

3. *махс.* Стройда (кильватер колоннасында) беренче булып баручы эскадра миноносецы яки җиңел крейсерның иске исеме.

ЛИ'ДЕРЛЫК *и.* Нинди дә булса эшчәнлектә беренче булу. *Әдәби хәрәкәтебездә, язучылар арасында ул [Галимҗан Ибраһимов] үзенең тоткан урынын, лидерлык вазифасын гүя һаман да саклый иде.* Ә. Еники. || Лидер булу, ярышта беренче урында бару. *Өч ел рәттән бу команда лидерлыкны үз кулында тота.* Соц. Тат.

ЛИ'ЗИС *и. мед.* Кайбер авырулар вакытында югары температураның акрынлап төшүе.

ЛИЗОЛ *и. махс.* Нәрсәгә дә булса дезинфекция ясау өчен кулланыла торган кызыл көрән төстәге майлы сыекча.

ЛИКБЕЗ *и.* 1. СССРда грамотасызлыкны бетерү — мәктәптә укымаган балаларны һәм олы кешеләрне укырга-язарга өйрәтү эше.

2. *сөйл.* Гадәттә олы яшьтәге грамотасызлар укый торган мәктәп. *Революция булып, авылда ликбез ачылгач, волостьтан килеп укытып киткән Касыйм хәлфәдән белемен арттырды, срогы тулып Касыйм хәлфә кайтып киткәч, Разияның үзенә ликбезны алып барырга тапшырдылар.* Г. Минский.

ЛИКВИДА'ТОР *и.* Ликвидаторлык тарафдары. *Меньшевиклар партияне таратырга, бетерергә тәкъдим итәләр, шуның өчен аларны ликвидаторлар дип атыйлар да.* СССР тарихы. *Бу агым [большевиклар] --- ликвидаторларга --- каршы каты фронт белән сугыш алып бара.* Г. Ибраһимов.

ЛИКВИДА'ТОРЛЫК *и.* РСДРП эчендәге революцион көрәш юлын инкяр иткән һәм пролетариатның легаль булмаган революцион партиясен бетерергә омтылган реакцион меньшевистик агым (1908—1912 е. е.). *Ликвидаторлык юлына басу.* □ *Контрреволюцион буржуаз либерализмның турыдан-туры йогынтысы белән меньшевистик оппортунизм ликвидаторлыкка әверелде.* КПСС тарихы.

ЛИКВИДА'ЦИЯ *и. сөйл.* Эшчәнлеген туктату (предприятие, учреждение һ. б. ш. турында). [*Лутов:*] *Ликвидация эшен сиңа тапшырырлар.* Ш. Камал.

ЛИКЁР *и.* Градусы шактый югары булган татлы исерткеч эчемлек. [*Парижда*] *эшчеләр һәм канцелярия хезмәтчеләре* [*кафеларга*] *җыелалар. Берәр стакан кофе яисә арзанлы вин руж* [*кызыл аракы*], *бик күпкә китсә, азрак ликёр аларга җитә кала.* Г. Гали.

ЛИКПУНКТ *и. к.* ликбез 2. *Иске җырның бары бер юлы „ликпунктта белем ала" дип үзгәртелгән.* М. Җәлил.

ЛИ'КТОР *и. тар.* Борынгы Римда югары администрация кешеләрен саклап-озатып йөрүче кеше.

ЛИЛЕ'ЙНИК *и.* Лаләчәләр семьялыгыннан төер-төер тамырлы күпьеллык үлән үсемлек, чәчәк. *Лилейник — кышка чыдам, аз талымлы үсемлек.* Йорт эшләре.

ЛИЛИПУТ *и.* 1. Буе нормаль булмаган бик кыска кеше, кәрлә.

2. *күч. сөйл.* Игътибарга лаек булмаган, әһәмиятсез, тоткан урыны буенча бик кечкенә кеше турында.

3. *күч.* Бик кечкенә күләмле предмет турында (мәсәлән, машина, станок һ. б. ш.).

ЛИЛ-ЛИЛ *ы. диал.* Казларны чакыру сүзе.

ЛИМАН *и.* Елганың диңгез суы баскан тамагы, шунда барлыкка килгән култык яки коры җир белән аерып алынган тозлы күл (шифалы лайга бай була). *Кара диңгезнең төньяк ярлары --- лиманнар дип атала торган кечкенә, сай сулыклы култыклар белән кискәләнгәннәр.* СССР физ. геогр. *Ачык диңгездән кайтып лиманга кергәндә җилкәннәрен бушата торган балыкчылардан әллә нинди серләр эзлиләр.* А. Таһиров.

ЛИМАНЛЫ: лиманлы сугару — яз көне эрегән кар суларын туфрактан өелгән вал ярдәмендә яки буа белән тотып торып, соңыннан валны яки буаны ерып җибәреп, туфракны 1 — 1,5 метр тирәнлектә дымландыру. *Корылыклы районнарда (бигрәк тә Идел буенда һәм Казахстанда) кар тоту һәм лиманлы сугару киң кулланыла.* СССР экон. геогр.

ЛИМБ *и. махс.* Почмак үлчәү приборларында әйләнәсе сызыклар белән тигез өлешләргә (градусларга, минутларга) бүленгән яссы металл бөжра. *Астролябия лимбы.*

ЛИМИТ *и.* Нәрсәне дә булса сарыф итү, тоту өчен билгеләнгән норма; берәр нәрсәнең рөхсәт ителгән микъдары. *Лимит билгеләү. Лимит кую.*

ЛИМИТСЫЗ *с.* Лимиттан тыш, лимит белән билгеләнмәгән. *Лимитсыз чыгым.*

ЛИМНО'ЛОГ *и.* Лимнология белгече.

ЛИМНОЛО'ГИЯ *и.* Гидрологиянең эчке сулыкларны (күлләрне, буаларны һ. б. ш.) өйрәнә торган тармагы.

ЛИМОН *и.* 1. Көньякта үсә һәм эре җимеш бирә торган мәңге яшел цитрус агачы. [*Мансур:*] *Ул гына да түгел, Андрюша исемле бер егетебез апельсин белән лимон үстерү турында хыяллана.* Р. Ишморат.

2. Шул агачның сары калын кабыклы, әчкелтем тәмдәге озынча түгәрәк хуш исле җимеше. *Лимон белән чәй эчү.* □ *Помидор һәм лимонда витаминнар күп.* Ботаника. *Александра Андреевна кулындагы сумкасыннан берничә пакет лимон, эфлисун, алма --- чыгарып, сәкенең буш урынына таратты.* М. Гали.

Лимон аракысы — лимон кабыклары салып төнәтелгән аракы. **Лимон бөтнеге** — составында эфир мае булган күпьеллык хуш исле үсемлек, мелисса. **Лимон гөле** — декоратив үсемлек (гөл) буларак үстерелә торган лимон куагы. *Лимон гөле яфракларында, шкаф, өстәл өсләрендә тәрәзә пәрдәсе челтәре кебек бизәкле күләгәләр уйный.* Г. Әпсәләмов. **Лимон кислотасы** — лимон җимешеннән һәм кайбер башка үсемлекләрдән табыла торган кислота (кулинариядә, медицинада, буяу эшендә һ. б. кулланыла).

ЛИМОНАД *и.* Сусынны басу өчен лимон яки башка җиләк-җимеш суы кушып ясалган татлы эчемлек. *Мәскәү фабрикантлары әүвәл лимонад эчереп, аннан соң [әхмәтсафаны] акрын гына сыра-фәлән дә эчәргә өйрәттеләр.* Ш. Мөхәммәдев.

ЛИМО'НКА *и.* 1. Тышкы рәвеше белән лимонга охшаган груша төре.

2. *сөйл.* Формасы ягыннан лимонны хәтерләткән калын тышчалы кул гранатасы. *Иртә белән --- су алырга килгән хатын-кыз, аяк астында аунап яткан „лимонка" гранаталарын күреп, су алмыйча, куркып кайтып китте.* И. Гази.

ЛИМО'ННИК *и.* Магнолияләр семьялыгыннан ак яки алсу чәчәк ата, тәме һәм исе белән лимонга охшаган кызыл җимеш бирә һәм үрмәләп үсә торган куаклык (җимешләре медицинада кулланыла). *Илебезнең Ерак Көнчыгышында үсә торган лимонникның [организмда матдәләр алмашын] стимуллаштыру үзлеге бар.* Соц. Тат.

ЛИМОНЛЫК *и.* Лимон бакчасы, лимон үсеп утырган җир.

ЛИМОН-САРЫ *с.* Лимон төсендәге сары. *Алтын көз [агачларның] бер ишеләрен сары, аксыл сары, лимон-сары төсләргә манды.* Г. Гобәй.

ЛИМОНЧЫ *и.* Лимон үстерүче. || Лимон белән сату итүче. *Итчеләр, лимончылар, толчокчылар, йорт-җир сату һәм алу эшендә маклер булып йөрүчеләр — барысы да килде.* С. Җәләл.

ЛИМУЗИН *и.* Кузовы ябык җиңел автомобиль.

ЛИ'МФА *и.* Кеше һәм умырткалы хайваннар гәүдәсендә организмның каны белән тукымалары ара-

сында матдәләр алмашын тәэмин итүче төссез сыекча. *Лимфаның химик составы.*

ЛИМФАДЕНИТ *и. мед.* Лимфатик төеннәрнең ялкынсынуы.

ЛИМФАТИК *с.* Лимфага караган, лимфага бәйләнешле булган. *Лимфатик бизләр.* □ *Ак тәнчекләр талакта, лимфатик төеннәрдә һәм сөяк җелегендә бүленү юлы белән үрчиләр.* Анатомия.

ЛИНГВИСТ *и.* Тел белеме белгече, тел галиме; телче. *Антик дөнья лингвистлары фигыльләрне бүтән сүз төркемнәреннән аера торган сигез төрле үзенчәлек санаганнар.* Л. Җәләй.

ЛИНГВИ'СТИКА *и.* Тел турындагы фән, тел белеме, тел гыйлеме. *Лингвистика тармаклары.*

ЛИНГВИ'СТИК *с.* Лингвистикага караган, шуңа бәйләнешле. *Лингвистик анализ. Лингвистик тикшерену.* □ *Быел Голландиядә чыга торган лингвистик журнал минем элегрәк чыккан берничә хезмәтемне басарга рөхсәт сораган.* М. Зәкиев.

ЛИНЕ'ЙКА I *и.* **1.** Туры сызык сызу яки берәр нәрсәнең озынлыгын үлчәү өчен гадәттә сантиметрларга, миллиметрларга бүленгән туры планка. [*Писарь*], *кәгазьләрен җәеп салып, ведомость төзер өчен линейка белән сызып утыра.* Ш. Усманов. [*Тимери*] *берничә урында туктап, итек кунычындагы тимер линейкасы белән Гөлсем культиваторының „тәпие" күпме тирәнлеккә төшүен үлчәп узды.* Г. Бәширов.

2. *хәрби.* Лагерьны турыпочмаклы участокларга — кварталларга бүлә торган юлларның берсе. *Алгы линейка. Аркылы линейка.*

3. Бер сафка тезелгән строй. *Линейкага тезелү.* || Хәрбиләр, пионерлар һәм укучыларның сафларга тезелүе. *Кичке линейка.*

ЛИНЕ'ЙКА II *и. иск.* Ике ягына да пассажирлар утыра торган, күп урынлы, ачык озын экипаж.

ЛИ'НЗА *и.* Ике кәкре яки бер кәкре һәм бер яссы өслек белән чикләнгән, үзе аша үтә торган яктылык нурларының кушылуын үзгәртә торган үтә күренмәле җисем; ясмык пыяла. *Кабарынкы линза. Батынкы линза.* □ *Гаряфи чәй янында үзенең ничек итеп фотоаппаратка линза — пыяла табуын сөйләп утырды.* А. Расих.

ЛИ'НИЯ *и.* **1.** Аралашу юлы (тимер юл, һава юлы, трамвай юлы, су юлы һ. б. ш. турында). *Трамвай линиясе. Тимер юл линиясе. Троллейбус линиясе.*

2. Аерым пунктлар арасындагы телефон, телеграф элемтәсе һ. б. ш.; шул элемтә өчен хезмәт итә торган җайланма. *Телефон линиясе.* □ [*Артамонов:*] *Линия бозык, Янбакты авылы белән Никольский арасында ун телеграмма баганасын кисеп алганнар.* Т. Гыйззәт. [*Телефонист:*] *Иптәш командующий! 51 нче линиядә.* Г. Бәширов. || Электр энергиясен ерак урыннарга тапшыру корылмасы. *Электр энергиясен тапшыру линиясе.* □ *Төп ток линиясе аерым районнарга бара торган параллель линияләргә бүленә.* Физика.

3. Окопларның, ныгытмаларның чиге; рубеж. *Оборона линиясе.* □ *Башкалар белән бергә Җамалилар ротасы да, җир асты юлларын үтеп, алдынгы линия окопларына кереп урнашты.* М. Гали.

4. *күч.* Юнәлеш, эш итү юлы; карашларның юнәлеше. *КПСС ның генераль линиясе.*

ЛИНКОР *и.* Дошман корабльләренә яки яр буе ныгытмаларына көчле артиллерия һөҗүме ясау өчен билгеләнгән иң зур хәрби корабль. *Йөз меңнәрчә яшь немецлар армиягә алындылар. Бер үк вакытта хәрби-һава көчләрен һәм су асты флотын торгызуга керешелде, шулай ук линкорлар һәм крейсерлар төзү башланды.* Иң яңа тарих. *Суда линкор, Күктә самолетлар, Җирдә танчкалар чабалар.* Ә. Ерикәй.

ЛИНО'ЛЕУМ *и.* Идәнгә җәю, стенаны каплау өчен һәм полиграфия эшендә кулланыла торган, махсус состав сендереп ясалган, су үткәрми торган калын тукыма. *Кулга, клеёнкага һәм линолеумга тигән кечкенә кара тапларын шырпы башы белән бетерергә мөмкин.* Йорт эшләре.

ЛИНОТИП *и.* Бөтен бер юлны тоташтан коеп җыя торган хәреф җыю машинасы (типографиядә). *Линотип бүлмәләре, литография бүлекләре берәм-берәм ачылдылар.* Г. Гали. *Ул чакта безнең хәзерге типографияләрдә эшләгән ротация һәм линотип кебек машиналар да юк иде.* С. Кудаш.

ЛИНОТИПЧЫ *и.* Линотипта эшләүче, линотипта хәреф җыючы.

ЛИНЧ: Линч суды (хөкеме) — АКШта реакцион буржуазиянең гадәттә негрларны бернинди тикшерүсез һәм судсыз ерткычларча җәзалап үтерүе. *Негрларны куркыту өчен әле дә булса Линч суды кулланыла.* Иң яңа тарих. *Мәрхәмәтсез Линч хөкеме һәлак итте аларны.* Ә. Ерикәй. **Линч законы** — негрларны тикшерүсез һәм судсыз җәзалау гадәте.

ЛИНЧЛАУ *ф.* Линч хөкеменә дучар итү, судсыз җәзалау. *Негрларны судсыз-нисез җәзалау — линчлау — Америкада әлегә кадәр дәвам итә.* Каз. утл.

ЛИПАРИТ *и. геол.* Составы буенча гранитка охшаган тоныкрак төстәге вулканик тау токымы. *Эффузив токымнарга липарит һәм кварцлы порфир керә.* А. Фаткуллин.

ЛИПО'ИД *и. махс.* Терек организмнарда һәм үсемлекләрдә була торган майсыман органик матдә. *Майсыман матдәләр, яки липоидлар да организмда зур роль уйныйлар.* Биология.

ЛИ'ПСИ *и.* Ирекле композициядәге парлы танец (Германия Демократик Республикасында ижат ителгән).

ЛИ'РА I *и.* **1.** Борынгы грекларда кыллы музыка коралы. *Тагын бер кырыйда — кара көмештән коелган мәһабәт бер лачын сыны, чын сәдәфтән эшләнгән лира һәм каләм сабы.* Г. Бәширов. *Афишаның иң югары* [*урынына*] *--- лира рәсеме --- басылган.* Ш. Камал. || *күч. шигъ.* Поэзия, поэтик ижат, шигърият символы; саз. — *Мин --- аңа багышлап шигырьләр язган булам. --- Саф йөрәктән булган мәхәббәтем мәсхәрә ителгәч, җансыз лирам сиңа азык була алмас.* Т. Гыйззәт.

2. Әйләнә торган түгәрәге булган, клавишлы һәм кыллы борынгы музыка коралы (Украинада һәм Белоруссиядә сакланып калган).

3. *астр.* Күкнең төньяк ярымшарындагы Киек Каз Юлы буена урнашкан бер йолдызлык. *Безнең Кояш системасы Лира һәм Геркулес йолдызлыклары юнәлешендә 20 км/сек тизлек белән хәрәкәт итә.* Астрономия.

ЛИ'РА II *и.* Италиядә һәм Төркиядә акча берәмлеге.

ЛИРИЗМ *и.* Сәнгать әсәрләрендәге эмоциональлек, аларның нечкә хисләр белән сугарылган булуы. *Тирән лиризм* [*М. Җәлил әсәрләренең*] *укучылар аңына тиз кереп урнашуына юл ача.* М. Гайнуллин.

ЛИ'РИК I *с.* **1.** Лирикага (1 мәгъ.) караган, лирика булып торган. *Лирик әсәрләр.* □ *Г. Камалның тезмә әсәрләре арасында --- җитди лирик шигырьләрне дә табарга мөмкин.* М. Гали. || Лирика элементлары булган; хисләр белән сугарылган. *Лирик драма.* □ *Романның беренче һәм алтынчы бүлек-*

ләре Мәрьямнең кичерешләре рәвешендә лирик керешләр белән башланган. Г. Нигъмәти.

2. Лирик әсәрләр яза торган. *Лирик шагыйрь.*

3. Хисләргә бай; лиризм белән сугарылган. [*Карәхмәт*] *гаҗәп лирик бер гашыйк тибы да* [*имеп*] *бирелгән.* М. Җәлил. || *күч. сөйл.* Артык эмоциональ, хисләр өстенлек иткән. *Шагыйрь халкы лирик йөрәкләрәк, Ләкин бүтәнчәрәк тормышта.* Ш. Маннур.

4. *муз.* Тавыш турында: тембры ягыннан йомшак яңгырашлы, йомшак аһәңле. *Лирик тенор. Лирик сопрано.*

ЛИ'РИК II *и.* Лирик әсәрләр язучы; лирик шагыйрь.

ЛИ'РИКА *и.* **1.** Әдәби әсәрләрнең кеше кичерешләрен, хисләрен һәм фикерләрен дулкынландыргыч итеп сурәтли торган, гадәттә шигъри формада язылган төре (эпос һәм драмадан тыш). *Б. Эйхенбаум „Шигырь мелодикасы" дигән әсәрендә лирика әсәрләрен аһәң ягыннан өч типка бүлә.* Г. Нигъмәти. || Шундый төр әдәби әсәрләр. *Г. Тукай лирикасы. Татар әдәбияты лирикасы.*

2. Нинди дә булса язучы әсәрләрендә эмоциональ элементлар, хисләр. *Лирика белән сугарылган әсәр.* □ *Җырларының көчле лирикасын мәхәббәткә алар биргәннәр.* Т. Гыйззәт.

3. *күч. сөйл.* Хис, кичерешләр. [*Лутов:*] *Лирикага биреләсез, иптәш Аникин. Сез шагыйрь булсагыз, матур гына поэмалар бирер идегез.* Ш. Камал. *Хисмәтнең дә шулай тормышында, Тирән лирикалар булган күк, Эпос та бар, озын проза да. Ш. Маннур.*

ЛИ'РИКЛЫК *и.* Лиризм белән сугарылган булу, хисләрнең байлыгы белән аерылып тору.

ЛИ'РИК-ДРАМА'ТИК *с.* **1.** Лирика һәм драма элементларын үз эченә алган (әдәби әсәрләр турында). *Лирик-драматик поэма.*

2. *муз.* Лирик һәм драматик тавыш арасындагы (җырчы тавышы турында). *Лирик-драматик сопрано.*

ЛИ'РО-ЭПИК *с.* Лирика һәм эпос элементларын үз эченә алган (әдәби әсәрләр турында). *Мәҗит Гафури лиро-эпик жанрда „Эшче" поэмасын иҗат итте.* Г. Хисмәтуллин.

ЛИРОКОЙРЫК *и.* Чыпчыклар семьялыгыннан көрән-сары төстәге кош (ата кошның койрыгы лирага охшаган була). *Кошлардан канатсыз тәвә кошы эму һәм лирокойрык тик Австралиядә генә яшиләр.* Дөнья кис. геогр.

ЛИСАН *и. иск. кит.* Тел. *Студентлар вә гимназисткалар илә үткән ел башында татар лисанында ике уен уйнадык.* Ф. Әмирхан.

ЛИСТАЖ *и.* Берәр басманың табак исәбе белән күләме. *Журналның листажы.*

ЛИСТО'ВКА *и.* Гадәттә көн үзәгендә торган политик эчтәлекле, агитацион характердагы басма тексты булган кәгазь бите. [*Революционерлар*] *урманда ясала торган маёвкалар, эшчеләр арасында таратыла торган листовка, прокламацияләр аркылы 8 сәгатьлек эш вакыты, эшчеләр контроле һәм башка таләпләр куярга эшчеләрне кузгаталар.* Ш. Камал. *Сугышчылар траншеяда җыелганнар һәм һөҗүмгә чакыручы листовкаларны укыйлар иде.* Г. Әпсәләмов.

ЛИТА'ВРА *и.* Күн белән тышланган берничә ярымшардан гыйбарәт бәрмә музыка коралы. *Тромбоннарның куркыныч яңгыраган авазлары, литаврәлар гүләгән, барабаннар дөбердәгән тавыш белән кушылып, тәмам җиңеп чыкты.* Ш. Хөсәенов.

ЛИТА'ВРАЧЫ *и.* Литаврада уйнаучы музыкант.

ЛИТВА *и.* Литва ССРда яшәүче төп халык атамасы. || *с. мәгъ.* Шул халыкка, аның культурасына бәйләнешле. *Литва теле. Литва сәнгате.*

ЛИТВАЛЫ *и.* Литва ССРда яшәүче төп халык кешесе. [*Орденга*] *каршы поляклар, литвалылар сугышканнар, шулай ук чехлар отряды да катнашкан.* Урта гас. тарихы. *„Корыч йөрәкле егет", — дип атаганнар аны литвалылар.* А. Шамов.

ЛИТВА'ЧА *рәв.* Литва телендә, литвалылар телендә. *Кыз белән малай литвача нидер сөйләшеп, елмаешып алдылар.* А. Әхмәт.

ЛИТЕ'ЙЩИК *и. к.* коючы. *Эш сөюе, тыйнаклыгы, акыллылыгы өчен Ольганы яраткан литейщикларның борчылырга нигезләре дә бар иде.* Г. Әпсәләмов.

ЛИ'ТЕР *и. махс.* Юл йөргәндә билет хакын түләмичә яки льгота белән барырга хокук бирә торган (аерым бер хәреф — литер белән билгеләнгән) таныклык, документ.

ЛИ'ТЕРА *и.* Типографиядә хәреф җыю эшендә кулланыла торган, металлдан һ. б. ясалган, бер башына кире ягы белән кабарынкы хәреф яки башка бер билге төшерелгән дүрткырлы кечкенә борыс.

ЛИ'ТИЙ *и. хим.* Табигатьтә саф хәлендә очрамый торган, йомшак һәм бик җиңел, көмеш сыман ак төстәге селтеле металл, химик элемент. *Селтеле металл булганга, литий су белән үзара актив реагирлаша.* Химия.

ЛИТО'ГРАФ *и.* Литография белгече.

ЛИТОГРА'ФИЯ *и.* **1.** Яссы таш өслегенә төшерелгән рәсемнән басма алу, шундый таштан рәсем бастыру ысулы. *Хәреф җыю, басу, төплау, литография, стереотип, хәреф кисү, хәреф кою --- эре производство төсен ала.* И. Рәмиев.

2. Шундый ысул белән бастырып алынган рәсем, басма.

3. Шундый ысул белән рәсем, басма эшләнә торган цех яки предприятие. *Казанда ачылган икенче хосусый типографиянең, дөресрәге, литографиянең хуҗасы татар кешесе була.* Каз. утл.

Литография ташы — 1) литография эшендә басма өчен материал булып хезмәт итә торган таш; 2) басма алу өчен өслегенә рәсем төшерелгән таш.

ЛИТОСФЕ'РА *и.* Җир шарының тышкы каты кабыгы. *Өске каты катлау — литосфера, уртанчы каты катлау — халькосфера һәм Җирнең үзәге — сидеросфера.* А. Фаткуллин.

ЛИТР *и.* 1000 кубик сантиметрга тигез булган сыеклык үлчәве. *Литр белән үлчәү.* || Шул күләмдәге сыеклык микъдары. [*Самсонов:*] *Анда бит миллион литр спирт саклана.* Т. Гыйззәт. [*Фермада бер сыер*] *ике мең өч йөз илле литр* [*сөт*] *бирде.* Ә. Еники.

ЛИТФОНД *и.* Язучылар союзы каршында язучыларның материаль хәлен һәм аларга культура-көнкүреш хезмәте күрсәтү эшен яхшырту максаты белән төзелгән җәмәгать оешмасы. *Безнең литфондта билгеле бер күләмдә акчалата пособие бирәләр.* М. Җәлил.

ЛИФ *и.* Хатын-кыз күлмәгенең билдән югары өлеше; кыса.

ЛИФТ *и.* Күп катлы биналарда һәм шахталарда пассажирларны һәм йөкне күтәрү-төшерү җайланмасы. *Санитарлар аларны носилкалар белән күтәреп кереп, лифтларга куеп, минут эчендә дүртенче, бишенче каттагы палаталарга менгереп урнаштырдылар.* М. Гали. *Шахтаның бер ягы. Лифтка керә торган зур капка күренеп тора.* Ш. Камал.

ЛИФТЁР *и.* Лифтта эшләүче эшче.

ЛИ'ФЧИК *и.* **1.** Хатын-кызларның күкрәкне каплап һәм күтәртеп тора торган эчке киеме, бюстгальтер.

2. Оекларны эләктереп кую өчен, балалар кия торган җиңсез кыса.

ЛИХАЧ *и. иск.* **1.** Бик купшы экипажга бик елдам ат җиккән извозчик; шул экипаж үзе. *Автомобильләр, лихачлар, җиңел ямщиклар халыкны ташый торалар.* Ф. Әмирхан. *Берәр лихачка утырып барганда яхшырак булыр иде Хөсәенгә.* А. Расих.

2. *сөйл.* Ялган батырлык күрсәтеп, юл йөрү кагыйдәләрен бозып транспорт йөртүче. *Лихачларга каршы көрәшү.*

ЛИХАЧЛЫК *и. сөйл.* Лихач (2 мәгъ.) булу. *Лихачлык — транспортның дошманы.*

ЛИ'ХТЕР *и.* Баржа тибындагы, гадәттә үзе йөрми торган судно (якын араларга йөк йөртү яисә зур суднолардан йөк бушату һәм аларга йөк төяү өчен файдаланыла).

ЛИЦЕВОЙ: лицевой счет — билгеле бер кеше исеменә ачылган счет. *Банкта лицевой счет ачу.*

ЛИЦЕИСТ *и. иск.* Лицейда тәрбияләнүче, лицейда укучы; лицейда белем алган кеше.

ЛИЦЕЙ *и.* **1.** *иск.* Революциягә кадәрге Россиядә: дворяннарның ир балалары өчен махсус, яхшы шартлары булган урта яки югары юридик ябык мәктәп.

2. Көнбатыш Европада: махсус урта мәктәп.

ЛИЦЕ'НЗИЯ *и.* **1.** Чит илгә товарлар чыгарырга яки чит илдән товарлар кертергә бирелгән рөхсәт; шундый рөхсәт язуы.

2. Нәрсәдән дә булса бушлай яки льгота белән файдалану хокукы.

ЛИЧИ'НКА I *и.* Күпчелек буынтыгаяклыларның, кайбер җир-су хайваннарының билгеле бер үсеш стадиясе (курчаклык стадиясенә кадәр булган үсеш чоры). Бу стадия вакытында организм күкәй тышчасыннан чыга һәм мөстәкыйль яши башлый, ләкин тышкы күренеше һәм төзелеше белән җитлеккән организмнан нык аерыла. || Шул стадиядәге организм үзе. *Күкәйләрдән личинкалар чыга, боларны гусеница (халык телендә корт) дип атыйлар.* Зоология.

ЛИЧИ'НКА II *и. махс.* Затворның винтовка көпшәсе каналын яба торган кисәге.

ЛИША'ЙНИК *и.* Җирнең өстендә, агач кайрыларында, таш өстендә үсә торган, бер организм тәшкил иткән гөмбә белән суүсемнән гыйбарәт түбән төзелешле үсемлек. *Лишайник үзенең әрсезлеге аркасында башка үсемлекләр яши алмый торган ялангач урыннарда да үсә ала.* Ботаника. *Лишайник бездә кыргыз далаларында --- очрый.* Робинзон әзл.

ЛИШУН *и. сөйл. тар.* СССРда 1936 елгы Конституция кабул ителгәнгә кадәр: изүче сыйныфка бәйләнешле булганлыктан, сайлау һәм башка гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителгән кеше.

ЛОБАН *и. зоол.* Кефальләр семьялыгына керә торган дингез балыгы, күшбашның бер төре.

ЛОББИСТ *и. полит.* АКШ конгрессында теге яки бу закон проектын раслатырга яки раслатмаска тырышучы монополияләрнең түләүле агенты. *АКШ конгрессына һәм хөкүмәтенә монополияләр лоббистлар ярдәмендә дә басым ясыйлар.* Иң яңа тарих.

ЛО'БЗИК *и.* Агач әйберләрне сырлап кисү өчен кулланыла торган, махсус рамкага куелган бик нечкә пычкы. *Кискән вакытта лобзик белән яхшы эшли белү бик әһәмиятле.* Йорт эшләре.

ЛОБОГРЕ'ЙКА *и.* Кистереп барылган игенне сәнәк белән ташлап калдыра торган гади ургыч. *Мостафа лобогрейка канатлары астына җыйнала барган солы кисентеләрен кулындагы агач сәнәк белән бертуктаусыз почмакка тартып, өемнәр ясый һәм бер чама үлчәү белән җиргә салып бара.* Ш. Камал. *Ике лобогрейка, --- канатларын алмаш-тилмәш әйләндереп, арыш урып килә.* Г. Гобәй.

ЛОВЕЛАС *и.* Хатын-кызлар артыннан йөрергә яратучы ир кеше, сөйрәлчек ир. *Карт ловелас.* □ *[Габдулла:] Сез, туташ, бәлки мине күп ловеласлардан берсе генә дип уйлый торгансыз?* Ф. Әмирхан.

ЛОВИЛЬ *с. махс.* Нәрсәне дә булса тоту, эләктерүгә бәйләнешле. *Ловиль инструментлар.* □ *Инструментның ике метрдан артыграк өлеше забойда торып калды. Бу очракта инде, һичшиксез, ловиль мастерын көтәргә кирәк иде, ләкин Кәрим --- инструмент өзеген [үзе] тотарга тырыша башлады.* Г. Ахунов.

ЛОГАРИФМ *и. мат.* Билгеле бер санны табу өчен нигез дип аталган санны дәрәҗәгә күтәрергә кирәк булган дәрәҗә күрсәткече. *Логарифмнар таблицасы.* □ *Дәрәҗә һәм нигез бирелгәндә, дәрәҗә күрсәткечен табу гамәле бирелгән нигез буенча бирелгән санның логарифмын табу дип атала.* Алгебра.

Логарифм линейкасы — төрле-төрле исәпләүләр өчен хезмәт итә торган әсбап, исәпләү линейкасы. *Илбарис инде торып киенгән һәм, стаканнан эчә-эчә, логарифм линейкасы белән нидер исәпләп утыра иде.* С. Сабиров.

ЛОГАРИФМИК *с. мат.* Логарифмнарга караган, логарифмын исәпләү өчен хезмәт иткән. *Логарифмик тигезләмә.*

Логарифмик линейка — *к.* логарифм линейкасы. *Исәпләгәндә таблицалардан һәм логарифмик линейкадан файдаланырга тәкъдим ителә.* Геометрия.

ЛОГАРИ'ФМЛАУ *ф. мат.* Бирелгән санның логарифмын табу. *Алгебраик тәгъбирне логарифмлау.*

ЛО'ГИК I *и.* Логиканы белүче кеше, логика белгече.

ЛО'ГИК II *с.* **1.** Логикага (1 мәгъ.) караган, логикага бәйләнешле. *Логик категорияләр. Логик анализ.*

2. Логика законнарына туры килгән, логика законнарына нигезләнгән. *Алкогольне даими куллану аркасында --- логик фикерләү сәләте кими.* Анатомия.

3. Нәрсәнең дә булса характеры, эчке закончалыклары белән бәйләнгән, закончалыклы. *Либреттода вакыйгалар уңышлы итеп, логик эзлеклелек белән үстерелә.* М. Җәлил.

Логик басым *лингв.* — җөмләдә мәгънәсе белән иң әһәмиятле булган сүзнең башкаларына караганда көчлерәк интонация белән әйтелүе. *Логик басым төшкән сүз.*

ЛО'ГИКА *и.* **1.** Фикерләүнең законнары һәм формалары турындагы фән. *Формаль логика. Диалектик логика.*

2. Табигать, җәмгыять һәм фикерләү күренешләренә хас булган эчке закончалык. *Ул --- сыйнфый көрәш логикасын төшенү дәрәҗәсенә барып җитә алмады.* М. Җәлил.

3. *сөйл.* Берәр нәрсә турында караш, мәсләк. *Шундый гаҗәеп бер логика белән Нургали эшкә тотынмакчы була, аңарда дәрт, энергия, ачу һәм ярсу — барысы бергә кайный.* Ә. Еники.

ЛО'ГИКАЛЫ *с.* **1.** Логика законнарына нигезләнгән, логика законнарына туры килгән. *Логикалы фикер йөртү. Логикалы җавап.*

2. Эзлекле рәвештә фикер йөрткән, эш йөрткән. *Логикалы кеше.*

ЛО'ГИКАЛЫЛЫК *и.* Логикалы булу. *Нәтиҗәләрнең логикалылыгы.*

ЛО'ГИКАСЫЗ *с.* Эзлекле булмаган, каршылыклы, логикасы булмаган. *Логикасыз җавап.*

ЛО'ГИКАСЫЗЛЫК *и.* Логикасыз булу. *Фикернең логикасызлыгы.* □ [*Г. Камал типларында*] *сабыйларча логикасызлык, акылсызлык та гәүдәләнә.* Г. Кашшаф.

ЛОГОГРИФ *и.* Башваткычның бер төре; бу төрдәге башваткыч, тиешле сүзне уйлап табып, андагы аерым иҗекләрне яки хәрефләрне алыштырып кую яки төшереп калдыру юлы белән чишелә.

ЛОГОПЕД *и.* Логопедия белгече.

ЛОГОПЕ'ДИЯ *и.* Сөйләмдәге кимчелекләр (сакаулык, тотлыгып сөйләү һ. б.) һәм аларны дәвалау турындагы фән.

ЛО'ДЖИЯ *и.* Ян стеналары булган һәм өсте ябулы балкон яки берәр бинага керү өчен хезмәт итә торган шундый бүлмә. *Һәр йортка алты бүлмә, алты лоджия арта дигән сүз бу.* М. Маликова.

ЛО'ЖА I *и.* Тамашачылар залының стенасы буенда берничә кеше утырырлык итеп ясалган аерым бүлем. [*Фәхри*] *партер ишеге төбенә аягүрә басып тыгылган халыкны ерып, этәреп, кысыла-кысыла фойега чыкты да Гәүһәрләр утырган ложага таба борылды.* Г. Ибраһимов. *Концерт башланыр алдыннан Бикмөхәммәтевне култыклап илтеп ложага утырттылар.* Ш. Камал.

ЛО'ЖА II *и.* Мылтык, винтовка яки автоматның көпшә беркетелгән агач өлеше.

ЛО'ЖА III *и. иск.* Масон оешмасының бүлеге.

ЛО'ЗУНГ *и.* **1.** Берәр җитәкче идеяне, бурычны яки политик таләпне белдерә торган кыска өндәмә; бик кыска формадагы шундый әүтәлекле мөрәҗәгать. *Большевиклар партиясе җитәкчелеге астында „Долой сатлык министрлар!", „Бетсен сугыш!", „Бөтен власть Советларга!" дигән лозунглар белән эшче-солдат массалары урамнарга чыктылар.* Т. Гыйззәт. [*Хәсән*] *речен барыбыз өчен дә сугышчан лозунг булып әверелгән сүз белән тәмамлады: „Яшәсен социалистик революция!"* К. Нәҗми.

2. Шундый өндәмә язылган плакат. [*Клубны*] *кызыл флаглар, лозунглар, революция юлбашчыларының рәсемнәре белән бизәгәннәр.* М. Гали.

ЛОКАЛИЗА'ЦИЯЛӘНҮ *ф. кит. к.* локальләшү.

ЛОКАЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф. кит. к.* локальләштерү.

ЛОКАЛЬ *с.* Билгеле бер урынга хас булган, билгеле бер чикләрдән чыкмаган; җирле. *Локаль сугышлар.*

ЛОКАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф. кит.* Билгеле бер чикләр белән чикләү, билгеле бер чикләрдән чыгармау. *Эпидемияне локальләштерү.*

ЛОКАЛЬЛӘШҮ *ф. кит.* Мәгълүм чикләрдән чыкмыйча, бер урында туплану, җыелу.

ЛОКА'ТОР *и. махс.* Берәр җисемнең урынын анардан кайткан тавыш яки радио дулкыннары ярдәмендә билгели торган аппарат. *Самолет төшү урынына килеп җитәргә 50—60 километрлар калгач, локаторларның берсе аны үзенең радионуры белән тота.* Уйлаучы машиналар.

ЛОКА'УТ *и.* Предприятиене ябып, эшчеләрнең барысын эштән чыгару (буржуазиянең эшчеләр сыйныфына каршы көрәш формасының бер төре). *Фабрикантлар һәм заводчиклар локаутлар игълан иттеләр — предприятиене яптылар һәм эшчеләрне күпләп эштән чыгардылар.* КПСС тарихы. *Бу заводның локаут ясап, яшенә-картына, иренә-хатынына карамаенча, урамнарга чыгарып, эшчеләрне газаплаганы мәгълүмдер.* Урал.

ЛОКМА *и.* Бер кабым ашамлык (ит, икмәк һ. б. ш). — *Бер-ике локма өчен ерткыч бер хайванга үзеңне кол кылгансың.* Г. Тукай. [*Сакчы:*] *Иртәдән бирле авызга бер локма капкан юк.* К. Тинчурин. || Кисәк (ашамлык турында). *Тураучылар үзләре дә ким куймыйлар, авызлары даим селкенә, күп вакыт иң симез локмаларны елт иттереп үзләре йоталар иде.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Бер кабым, бер кабарлык (ит, икмәк һ. б. ш.). *Бүген дүртенче тәүлек инде, бер локма икмәк капканнары юк.* Ә. Еники. [*Нәсимә:*] *Иртәдән кичкә кадәр бер локма аш капмадым.* Ш. Камал.

ЛОКОМОБИЛЬ *и.* Төрле машиналарны хәрәкәткә китерә торган пар двигателе. *Локомобиль казаны. Локомобиль заводы.*

ЛОКОМОБИЛЬЧЕ *и.* Локомобильдә эшләүче.

ЛОКОМОТИВ *и.* Рельслар буйлап поезд яки вагоннар йөртә торган машина (паровоз, тепловоз, электровоз һ. б). *Локомотивлар паркы.*

ЛОМ *и.* Нинди дә булса каты нәрсәне (боз, таш) вату, ваклау өчен бер яки ике башы да очланган авыр тимер таяк. *Болар ломнар белән таш ваталар иде.* Н. Дәүли. *Боз тауларын тигезләргә кирәк. Менә шуның өчен безнең батырларның кулларында лом, кирка, көрәк.* А. Алиш.

ЛОМБАРД *и.* Әйберне закладка алып, шуның өчен вакытлыча бурычка акча биреп тора торган учреждение. *Мин дә бер пальтомны илтәм, әйдә, дус, ломбардка бар.* Г. Тукай. [*Габделбасыйр:*] *Ломбард бар, теге бишмәтне анда салырга мөмкин.* Ф. Әмирхан.

ЛОМОВОЙ *и. сөйл.* **1.** Ат белән йөк ташучы, йөк йөртүче. [*Хәйретдин*] *кыш буе шунда ломовой — ямщик булып эшли.* М. Гали. [*Вафа:*] *Йөк ташучы ломовойларга күз-колак булырга куштым. Бары да, карарбыз, диделәр.* Т. Гыйззәт.

2. *с. мәгъ.* Авыр йөк ташу өчен билгеләнгән, хезмәт итә торган. *Ломовой арбаларына салынган пулеметларны, утын төсле әрдәнәләп төялгән винтовкаларны каядыр күчерәләр.* К. Тинчурин.

Ломовой извозчик — 1) *к.* ломовой (1 мәгъ.); 2) авыр йөк йөртү өчен билгеләнгән экипаж (арба, чана). *Шәрәфи карт ломовой извозчик белән җеназа ящигы алып килде.* Ш. Камал.

ЛОМОНОС *и. бот.* Казаякчалар семьялыгыннан үрелеп үсә торган күпьеллык үлән яки куак үсемлек. [*Тропикта*] *һәрбер агач колмак үләне кебек лиана, ломонос, виноград үсемлекләре белән үтә алмаслык хәлдә чорналган.* А. Фаткуллин.

ЛОНГЕТТ *и. мед.* Организмның сынган сөякләрен ялгап үстергәндә кулланыла торган, гипстан ясалган алынмалы повязка. *Лонгетт салу.*

ЛО'НЖА *и. махс.* **1.** Атны түгәрәк буйлап йөртергә өйрәткәндә кулланыла торган озын бау, корда.

2. Акробатикага өйрәнүчеләрне яки цирк гөмбәзе астында бик катлаулы номерлар белән чыгыш ясаучы артистларны тоттырып тору өчен кулланыла торган бау.

ЛОНЖЕРОН *и. тех.* Төп буй борыс (автомобиль рамында, самолетның канатында яки корпусында, кайбер көймәләрдә һ. б.).

ЛОПАРЬ *и.* Саам халкының әлекке атамасы.

ЛОП-ЛОП *аваз ияр. к.* лап-лап.

Лоп-лоп итү — шундый тавыш барлыкка китерү. [*Песи малайлары*] *лоп-лоп итеп идәнгә егылып төшәләр һәм сәке артына себертәләр.* Һ. Такташ.

ЛОПТЫРДАУ *ф. сөйл. к.* лаптырдау. *Баш өстеннән лоптырдап ярканат очып китте.* Г. Ахунов.

ЛОПЫРДАУ *ф.* Атлаганда өс киемнәре озын булу аркасында, җилдә берәр нәрсә җилфердәгәндә һ. б. ш. очракларда үзенә бертөрле тавыш барлыкка килү. *Өстенә [Газиз] лопырдап торган озын чикмән кигән.* М. Галәү.

ЛОРД *и.* Англиядә югары катлау дворяннарның нәселдән нәселгә күчә барган титулы, шул титулга ия булган кеше. *Мәшһүр инглиз шагыйре лорд Байронның исемен ишетмәгән кеше аздыр дип уйлыйм.* Г. Тукай. *Илебезне җимерер, талар өчен, Комсыз байлар, лордлар, түрәләр Бүген анда, канлы Европада, Тәре үбеп антлар бирәләр.* Һ. Такташ.

Лордлар палатасы — Англия парламентының югары палатасы.

ЛОРД-КА'НЦЛЕР *и.* Англиядә лордлар палатасы председателе һәм суд эшендә югары хезмәт урынындагы кеше.

ЛОРДЛЫК *и.* Лорд дәрәҗәсе, лорд титулы.

ЛОРД-МЭР *и.* Лондонда һәм Англиянең кайбер башка шәһәрләрендә муниципалитет башлыгы.

ЛОРНЕТ *и.* Сапка утыртылган күзлек, саплы күзлек. *Лорнет белән карау.*

ЛОТ I *и.* Судно бортында торып, суның тирәнлеген үлчи торган әсбап. *Тәҗрибәле бурлаклар, шпильдә эшләүгә караганда, лотта яки рейдта эшләүне артыграк күрәләр.* М. Гали. *Капитан салчыларга лотларны күтәрергә боерды.* С. Сабиров.

ЛОТ II *и.* Русларда метрик система кертелгәнче кулланылган, 12,8 граммга тигез авырлык үлчәве.

ЛОТЕРЕ'Я *и.* Билетларга акча һәм әйбер отышлары уйнату. *Брюллов шул көннәрдә Жуковскийның рәсемен эшләгән икән, шуны лотереяга куялар да, килгән акча белән булачак шагыйрь, хәзер рәссам булган Шевченконы коллыктан котылдыралар.* Г. Ибраһимов. *Осоавиахим лотерея билетларының һәр тиражы саен Гәрәй почтага йөгерә.* А. Алиш.

ЛОТО *и.* Аерым кәгазьгә (картага) төшерелгән номерларны (яки рәсемнәрне) берәү әйтеп торып, уйнаучылар ябып бара торган һәм цифрлар (яки рәсемнәр) рәтен кем элек ябып бетерсә, шул ота торган уен. *Илдар белән Саниә, Маратка --- әһәмият бирмичә, рәсемле лото уйнап утыралар.* Г. Гобәй. *Җәдитчеләр тарафыннан оештырылган клуб күренешләрендә иң зур культура эше булып лото, домино уйнау күрсәтелә.* М. Гали.

ЛОТОК *и. сөйл.* Урамда сату итү өчен ачык прилавка. *Лотокта сату итү.*

ЛОТОКЧЫ *и. сөйл.* Лотокта сату итүче.

ЛО'ТОС *и. бот.* Ашарга яраклы җимеш бирә һәм зур матур чәчәк ата торган көньяк су үсемлеге. *Лотос чәчәкләре бәйләме белән өйләрне, храмнарны, мумияләр салынган зиннәтле каберләрне бизәгәннәр.* Робинзон эзл.

ЛОХ *и. бот.* Ашарга яраклы җимеш бирә торган, хуш исле чәчәкле, көмешсыман тар яфраклы куак.

ЛО'ЦИЯ *и. махс.* 1. Диңгез, елга һәм яр буйларының тасвирламасы, шулай ук суднолар йөртү өчен гидрология һәм метеорология мәгълүматлары бирелгән белешмә-кулланма. [*Иван Кириллович:*] *Дөрес, лоциясе дә, навигациясе дә, компасы да, локаторы да кирәк.* С. Сабиров.

2. Корабльләр йөртү турындагы фәннең диңгезләрдә, елгаларда йөзү шартларын өйрәнә торган бер тармагы.

ЛО'ЦМАН *и.* 1. Билгеле бер урындагы йөзү шартларын яхшы белүче һәм аннан фарватер буйлап суднолар үткәрүче белгеч. *Салны борырга тиеш булган урыннарда вышкадагы лоцман салны борырга кирәк икәнлек турында сигнал бирә.* М. Гали. *Барып җитәргә утыз километрлар чамасы калганда, Чишмә елгасы тамагында безне махсус лоцман каршы алырга, юлның калган өлешендә шул озата барырга тиеш иде.* С. Сабиров.

2. Ставридалар семьялыгыннан корабльләр һәм әре балыклар (бигрәк тә акула) артыннан азык эзләп ерак араларга йөзеп бара торган кечерәк бер балык.

ЛО'ЦМАНЛЫК *и.* Лоцман (1 мәгъ.) эше, лоцман вазифасы. *Үзе капитанлык итеп, төпчеге Сашаны лоцманлыкка өйрәтте.* Г. Минский.

ЛОЯЛЬ *с.* Дәүләт властена, власть органнарының гамәлдәге законнарына һәм карарларына чын-чыннан яки кайбер вакытта тыштан гына, формаль рәвештә генә турылыклы булган. *Дөрес, безнең илдә руханиларның күбесе лояль, битараф карашта тораллар.* Соц. Тат. || *сөйл.* Яхшы мөнәсәбәттә булган, яхшы мөнәсәбәт күрсәтүче. *Лояль кеше.*

ЛОЯЛЬЛЕК *и.* Лояль булу, лояль мөнәсәбәттә булу. *1947 елда Трумэн дәүләт хезмәткәрләренең лояльлеген тикшерү турындагы приказга кул куйды.* Иң яңа тарих.

ЛУБОК *и.* Берәр төрле бик гади рәсем бастырып чыгару өчен өстенә чокып сурәт ясалган юкә такта. || Шундый тактадан бастырып алынган рәсем. *Лубок остасы.*

ЛУ'ДА *и.* Аккургаш белән каракургаш эретмәсе (тутыкмасын өчен металл әйберләрнең өстенә йөгертелә).

ЛУДИ'ЛЬЩИК *и.* Металл әйберләргә луда йөгертү остасы.

ЛУ'ЗА *и.* Бильярд өстәле кырыйларында һәм почмакларында шар төшерү өчен астына челтәрле кечкенә капчык беркетеп куелган тишек. *Кургашын шарларны шалтыратып лузага салучылар да юк түгел иде.* А. Әхмәт. *Матур уйныйлар, сак уйныйлар. Алдан сөйләшеп куйгандай, лузага тәгәрәп төшү өчен „аякларын салындырган" шарларга тимиләр.* М. Хәсәнов.

ЛУИДОР *и.* Франциядә 20 — 25 франкка тигез булган борынгы алтын тәңкә.

ЛУНАТИЗМ *и.* Төнге йокы вакытында торып, үзүзен белештермичә йөрүдән һәм башка төрле автомат хәрәкәтләр башкарудан гыйбарәт халәт, авыру. *Лунатизм белән җәфалану.*

ЛУНА'ТИК *и.* Лунатизм белән авыручы кеше. [*Мостафа:*] *Нәрсә сез, лунатиклар кебек, төн йокыгызны калдырып, Идел буенда кайнаша идегез?* Г. Гобәй.

ЛУ'ННИК *и. неол.* Айны һәм Ай тирәсе киңлекләрен тикшерү-өйрәнү өчен ракета белән җибәрелгән фәнни станция. *Советлар Союзы җибәргән лунникларның очышы белән Айны һәм Ай тирәсе киңлекләрен өйрәнүдә яңа сәхифә ачылды.* Соц. Тат.

ЛУ'ПА *и.* Предметларны зурайтып күрсәтү өчен кысага утыртылган кабарынкы пыяла; ясмык пыяла. *Өстәлгә иелгәннәр, берсе лупа белән, икенчесе балчык валчыкларын микроскопка куеп карый.* А. Әхмәт.

ЛУРТ-ЛУРТ *обр.ияр. к.* лерт-лерт. *Лурт-лурт юырту.*

ЛУС-ЛУС *обр.ияр. к.* лерт-лерт. *Лус-лус юырту.* □ *Шулай тирән уйга чумып утырганда, лус-лус басып, коридор буйлап Исхак Еникеев килә.* Ф. Балыкчы.

ЛУЩИ'ЛКА *и. сөйл. к.* лущильник. *Күрше станциядән дүрт лущилка алып кайтканнар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЛУЩИ'ЛЬНИК *и.* Туфракны көпшәкләндерә, йомшарта, чүп үләннәрдән арындыра торган авыл хуҗалыгы машинасы. *Участокны ЛД-10 маркалы дисклы лущильниклар ярдәмендә дүрт эздән эшкәрттек.* Соц. Тат.

ЛЫБЫ *и. диал.* Юкәдән үрелгән кәрзин.

ЛЫБЫРДАУ *ф. сөйл.* Ишетелер-ишетелмәс итеп аңлаешсыз сөйләшү. *Сүзләрне бик үк ачык әйтми, авыз эчендә лыбырдатыбрак сөйли.* Н. Фәттах.

ЛЫБЫРДЫК *и. сөйл.* 1. Ишетелер-ишетелмәс итеп аңлаешсыз сөйләүче, лыбырдаучы.

2. Такылдык.

ЛЫБЫР-ЛЫБЫР *аваз ияр.* Ишетелер-ишетелмәс итеп аңлаешсыз сөйләшү вакытында барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лыбыр-лыбыр килү (сөйләү) — к. лыбырдау. *Лыбыр-лыбыр килә торган, алсу битле, кечкенә борынлы гүзәл балаларны* [*яратасыздыр*]. Каз. утл.

ЛЫҒРЫМ *рәв. диал.* Шыгрым, туп-тулы. *Клубта халык лыгрым тулган.*

ЛЫҒЫР *рәв. диал. к.* лычма. *Итек лыгыр су булган.*

ЛЫГЫРДАВЫК *и. сөйл. к.* лыгырдык 1. [*Р. Ильясның*] *Галиева типик „намуслы лыгырдавык" булган да чыккан.* М. Җәлил. | *с. мәгъ.* [*Әтәч:*] *Лыгырдавык Сертотмаска Зур эш тапшырдык.* А. Алиш.

ЛЫГЫРДАУ *ф. сөйл.* 1. Белер-белмәс берәр нәрсә турында сөйләү, әйтү; сөйләшү.— *Яшь башың белән бик күп лыгырдыйсың, үскәч, зур булгач, һәммәсен дә белерсең әле.* Г. Иделле. [*Миңсылу:*] *Кемнең теленә ни килсә, шуны лыгырдый.* Ш. Камал. || Сөйләргә ярамаганны сөйләү. [*Нәбиулла:*] *Бергә булмау яхшырак, я идарәгә барып лыгырдар.* Т. Гыйззәт.

2. Әһәмиятсез, җитди булмаган сүз сөйләү; сафсата сату.— *Лыгырдап утырасыз шунда, чүбек чәйнәп.* Г. Камал. [*Данилов:*] *Ташла әле, зинһар, бушка лыгырдавыңны!* Г. Бәширов. — *Вәсилә ханымның рухына туры килмәгән нәрсә килеп чыгар, коры лыгырдау булып кына калыр, дип шикләнәм.* Ф. Хөсни.

ЛЫГЫРДЫК *и. сөйл.* 1. Һәрвакыт лыгырдаучы, буш сүз сөйләүче, сафсата сатучы кеше. | *с. мәгъ. Лыгырдык хатын.*

2. Буш сүз; сафсата. [*Старшина:*] *Галим хәзрәт, --- аның китапларын күрәсе иде.* [*Галим хәзрәт:*] *Сөйләмә шул юкны!! Күрдем мин аның ул лыгырдыкларын.* Г. Ибраһимов.

ЛЫГЫР-ЛЫГЫР 1. *аваз ияр.* Су, ботка һ. б. ш. нәрсәләр кайнаганда чыккан тавышны белдерә. *Самовар кайный, лыгыр-лыгыр килә.* М. Әмир.

2. *рәв. к.* лыкы-лыкы. *Лыгыр-лыгыр сөйләшү.*

ЛЫК *рәв. диал. к.* лыкма. *Мосафирханә зур-зур бүлмәләрдән гыйбарәт --- бер йорт булып, һәрбер бүлмәсендә лык тулган мосафирлар.* М. Гафури.

ЛЫКМА *рәв. диал.* Шыгрым, бөтенләй, чигенә кадәр. *Лыкма тулган.*

ЛЫКЫЛДАУ *ф.* 1. *сөйл.* Сөйләү; сөйләп тору; туктаусыз сөйләү. *Мәүлиха түти аның бу лыкылдавын бер дә ошатмаса да, монысында ул да авызын ермыйча булдыра алмый.* Г. Бәширов. [*Кызбикә:*] *Нәрсәләр лыкылдыйсыз, усаллар?* М. Фәйзи.

2. *диал.* Бытылдау (балалар сөйләве турында). *Мохтар аның сүзләренә күбесенчә мәгънәсез балалар лыкылдавы шикеллерәк карый.* Ш. Камал.

ЛЫКЫЛДЫК *и. сөйл.* Күп сөйләүче, туктаусыз ләчтит сатучы. | *с. мәгъ. Лыкылдык хатын.*

ЛЫКЫ-ЛЫКЫ *рәв.* Туктаусыз сөйләп-сөйләшеп тору турында.

Лыкы-лыкы килү (сөйләү) — *к.* лыкылдау (1 мәгъ.).

ЛЫКЫР *с. диал.* Пычрак, юеш.

ЛЫКЫРДАТУ *ф. диал.* Пычрату, пычракка буяу, юешләтү.

ЛЫКЫРДАУ *ф. диал.* Пычрану, пычракка буялу, юешләну. *Бала пычракта лыкырдый.*

ЛЫКЫРДЫК *и. диал.* Шапшак кеше, быкырдык.

ЛЫП I *аваз ияр.* Кинәт утырганда, егылганда яки берәр нәрсәне куйганда барлыкка килгән тавышны белдерә. [*Әпипәнең*] *шунда ук бөтен гәүдәсе тотрыксызланып, баскан урынында „лып" итеп җиргә утырды.* Г. Бәширов. *Габделкаюм да көч-хәл белән беренче көлтәне бәйләп, бик куанып --- „лып" итеп җиргә утырткан иде, көлтә таралып китте.* М. Гали.

ЛЫП II *рәв. сөйл.* Кинәт, капыл. *Янып торган утлы күмер — көлгә салсаң, лып сүнәр. Мәкаль. Тау башында җил лып туктады.* И. Гази.

ЛЫП-ЛЫП *аваз ияр.* Берәр әйбер җилдә җилфердәгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә.

ЛЫПТЫРДАУ *ф. сөйл. к.* лыптыр-лыптыр килү. *Бары пароход көпчәкләренең лыптырдавы белән пароход борынының Идел суын шаулатып барганы гына ишетелә.* Г. Рәхим.

ЛЫПТЫР-ЛЫПТЫР *аваз ияр. к.* лаптыр-лаптыр.

Лыптыр-лыптыр килү — *к.* лаптырдау.

ЛЫПШЫРДАУ *ф. к.* ләшпердәү. *Аның лыпшырдаган симез гәүдәсе хәрәкәтсез; якасыннан ашып, бүртенеп торган муены кып-кызыл.* А. Расих.

ЛЫПШЫРДЫК *с. к.* ләшпердек. *Ә аның улы Мөрем лыпшырдык зур киемнәрдән, чырадай ябык кыяфәте белән мескен һәм кызганыч булып күренә иде.* А. Расих.

ЛЫПЫЛДАТУ *ф. сөйл. к. лыпырдату. Мичтә һаман коры утыннар дөрләп яна, җил чатыр брезентын лыпылдата.* Г. Әпсәләмов.

ЛЫПЫН *рәв. диал.* Яссы ягы белән, бөтен өслеген тидереп. *Утынны җиргә лыпын салу.*

ЛЫПЫРДАТУ *ф.* Җилнең нинди дә булса әйберне, киемне җилфердәтеп үзенә бер махсус тавыш чыгаруы турында.

ЛЫПЫРДАУ *ф. сөйл.* Җил исеп берәр әйберне җилфердәткәндә, озын кием киеп йөргәндә, шулай ук нинди дә булса предмет берәр нәрсәгә җиңелчә бәрелгәндә һ. б. ш. очракларда үзенә бер махсус тавыш чыгару. *Озын күлмәк лыпырдый.* Г. Тукай. *Ботинкаларга авыр балчык сыланды, шинель итәкләре авыраеп, аяк арасында лыпырдап йөдәтте.* Г. Бәширов. *Балыклар лыпырдашып идәнгә коела башладылар.* Р. Батуллин.

ЛЫПЫР-ЛЫПЫР *аваз ияр.* Җил исеп әйбер җилфердәгәндә, яфраклар селкенгәндә һ. б. ш. вакытларда барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лыпыр-лыпыр килү (итү) — *к.* лыпырдау. *Әлеге карт тирәк яфраклары да лыпыр-лыпыр килеп әкрен генә шаулыйлар иде.* Г. Галиев.

ЛЫПЫРТ *аваз ияр.* 1. Кая да булса сазга, ләмгә, суга һ. б. ш. килеп төшкәндә барлыкка килгән тавышны белдерә.

2. *хәб. функ. сөйл.* Үзенә бертөрле тавыш чыгарып килеп төшү, егылып төшү (сазга, суга һ. б.). *Әнвәр кулларын җәеп лыпырт түбәнгә!.. Бот төбеннән бата бу.* Э. Касыймов.

ЛЫРТ-ЛЫРТ *обр. ияр.* Ашыкмыйча гына, салмак кына юыртып баруны яки йөрүне белдерә. *Бүртә алаша лырт-лырт юырта.* Х. Кәрим. [*Ялчы хатын*], *һәр көн кояш белән бергә кузгалып, көн буенча лырт-лырт йөри.* Г. Ибраһимов.

ЛЫРЫК-ЛЫРЫК *обр. ияр. к.* лырт-лырт. [*Җирән кашка*] *лырык-лырык юыртып киткән була да, озаклямый тагын адымлауга күчә.* И. Гази.

ЛЫС-ЛЫС *обр. ияр. диал. к.* лус-лус. *Лыс-лыс чабу.*

ЛЫСТЫР *с. диал.* Искергән, эленеп-салынып торган. *Лыстыр күлмәк.*

ЛЫСТЫР-ЛЫСТЫР *аваз ияр. к.* лычкы-лачкы. *Юл пычрак, лыстыр-лыстыр ат тарта.* Н. Фәттах.

ЛЫЧ *рәв. диал.* Бөтенләй. *Лыч су. Лыч май.*

ЛЫЧКЫ *с. диал.* Бөтенләй чи, пешеп җитмәгән. *Лычкы ипи.*

ЛЫЧКЫ-ЛАЧКЫ *аваз. ияр.* Пычрак яисә су ерып барган вакытта барлыкка килгән тавышны белдерә. *Лычкы-лачкы. Каяндыр ерактан шундый тавыш ишетелә. Дә ул чокырга якынлашты.* Ф. Кәрим.

ЛЫЧКЫЛДАТУ *ф. сөйл.* Юеш җирдән барганда яки юеш аяк киеме белән йөргәндә һ. б. ш. вакытларда үзенә бертөрле тавыш чыгару; чапырдату. *Лычкылдатып бару.* □ [*Сыер су*] *эчеп бетергәч, урыныннан кузгалмый, эч пошырып, авызын лычкылдатып тора бирә.* М. Әмир.

ЛЫЧКЫЛДАУ *ф. сөйл.* Юеш аяк киеме белән йөргәндә, юеш җирдән барганда, гомумән берәр юеш нәрсә белән эш иткәндә үзенә бертөрле тавыш барлыкка китерү, чапырдау. [*Габитнең*] *чабатасы да лычкылдый башлады.* Ф. Кәрим. *Идән такталары астында баскан саен су лычкылдый.* Г. Әпсәләмов.

Лычкылдап тору — камырдан пешерелгән ашамлыкларның чи булуын белдерә. [*Мәликә:*] *Дхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән, бөтенләй лычкылдап тора.* Г. Камал.

ЛЫЧМА *рәв. сөйл.* Манма, бөтенләй, бөтенләе белән (юешләнү, чылану турында). [*Ибрайның*] *бөтен тәне лычма су булган, күлмәге юешләнеп аркасына ябышкан.* М. Әмир. [*Гөлнур*] *йөгереп лапаска керде, утын әрдәнәсе өстенә лычма су булган капчыгын салып атты.* Г. Ахунов.

ЛЫЧТЫРДАУ *ф. сөйл.* Пычтырдау, пычрану, лычкылдау. [*Ул*] *кер уа, лычтырдый, су чәчрәтә.* М. Әмир.

ЛЫШК *аваз ияр.* Борын тартып куйганда барлыкка килгән тавышны белдерә.

Лышк иттерү — шундый тавыш барлыкка китерү. *Малай лышк иттереп борынын тартты.* А. Гыйләҗев.

ЛЫШКЫЛДАУ *ф.* Лышык-лышык елау, сулкылдап елау, борын тарта-тарта елау. *Залдан ишетелә торган кәеф-сафа тавышлары, шау-шулар хәзрәтнең бу лышкылдавын әллә ничек җиңел һәм көлке итеп ишеттерәләр иде.* Ф. Әмирхан.

ЛЫШ-ЛЫШ *аваз ияр. к.* лышт-лышт. *Иңбашларының җиңелчә дерелдәвеннән, лыш-лыш борын тартуыннан Хәбир аның елавын аңлады.* Ш. Хөсәенов.

ЛЫШПЫРДАП: лышпырдап тору *диал.* — киемнең зур булып, эленеп-салынып торуын белдерә.

ЛЫШПЫРДЫК *с. сөйл.* Лышпырдап торган, эленеп-салынып торган, зур (кием турында). *Рәхим өстендәге лыпырдык зәңгәр халатка күз ташлады да үзалдына әрнеп елмаеп куйды.* А. Расих.

ЛЫШТ-ЛЫШТ *аваз ияр. к.* лышык-лышык. *Мин мондый вакытларда, гаепле булып күренү кирәктер дип, лышт-лышт борын тартып --- ашка кайта торган идем.* Г. Минский.

ЛЫШТЫК-ЛЫШТЫК *аваз ияр. к.* лыштыр-лыштыр. *Чүәкләр лыштык-лыштык сөйрәлеп киләләр.* Ф. Хөсни.

ЛЫШТЫР *с. сөйл.* Өстерәлеп лыштырдый торган; зур (аяк киеме турында). *Аякларында* [*егетнең*] *олы-олы лыштыр галошлар.* Р. Төхфәтуллин.

ЛЫШТЫРДАТУ *ф. сөйл. к.* лаштырдату. *Бабайның иске кәвешен лыштырдатып узып китүен инде онытып бетердек.* Г. Бәширов.

ЛЫШТЫРДАУ *ф. сөйл. к.* лаштырдау. *Галошлар лыштырдый.*

ЛЫШТЫРДЫК *с. сөйл. к.* лыштыр. *Лыштырдык итекләр.*

ЛЫШТЫР-ЛЫШТЫР *аваз ияр. к.* лаштыр-лоштыр. [*Шөҗәгъ:*] *Мин мәдрәсәгә кергән чагында, ул, яланаягына чабата киеп, урам буенча шул чабатаның киндерәсен өстерәп, урам кибетенә лыштыр-лыштыр бара торган малай иде.* Г. Камал.

ЛЫШЫК-ЛЫШЫК *аваз ияр.* Борынны еш тартканда яки сулкылдап елаганда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Хәзрәт, башын өстәл өстенә куеп, лышык-лышык елый башлады.* Ф. Әмирхан. *„Кал, дигәнеңне дә ишеткән юк әле моңарчы", — диде карчык, лышык-лышык борынын тартып.* А. Гыйләҗев.

ЛЫҖБЫРАУ *ф. диал.* Булдыксызлык күрсәтү, жебү.

ЛЫҖЫРДАУ *ф. сөйл.* Жебеп изрәү, эреп пычрак барлыкка килү (мәсәлән, аяк астында).

ЛЬГО'ТА *и.* Нинди дә булса вазифа үтәүдән, йөкләмәдән, түләүдән өлешчә яки тулысынча азат итү. *Льгота бирү.*

ЛЬГО'ТАЛЫ *с.* Льгота бирелә торган, льготага мөнәсәбәтле. *Льготалы билет. Льготалы тариф.* □ *Ярлы һәм урта хәлле крестьяннарга акчалата кредит, льготалы шартларда орлык һәм азык ссудалары бирелде.* Политэкономия.

ЛЬЁ *и.* Франциядә чама белән 4,5 *км* га тигез булган борынгы озынлык үлчәве.

ЛЮИЗИ'Т *и.* Төссез сыекчадан гыйбарәт тотрыклы агулаучы матдә. *Люизиттан зарарлану.*

ЛЮК *и.* **1.** Эчкә керү, түбәнгә төшү өчен капкач белән ябыла торган тишек. *Сәхнәдәге люк. Корабль палубасы люгы.* □ *Танкистлар, люкларын ябып, танкларына утыралар.* Г. Әпсәләмов.

2. Суднода, самолетта ату коралы өчен тишек. *Самолет түшәмендәге люкта пулемёт янында пулемётчы юк.* Г. Гобәй. || Самолетта бомба ташлау тишеге. [*Самолетның*] *люкларыннан бомба сибелде.* Ш. Маннур.

ЛЮКС I *и. физ.* Яктыртылу дәрәҗәсен үлчәү берәмлеге. *Яктылык агышына перпендикуляр торган 1 м өслекнең 1 лм яктылык агышы белән тигез яктыртылуы 1 люкс була.* Физика.

ЛЮКС II *и.* Бик яхшы җиһазландырылган кибет, гостиница номерлары, купелар, кауталар һ. б. ш. нәрсәләрнең исеме. [*Гайнулла:*] *Таныш чүпрәк. Люкстан мендәр тышына дип алган идем.* А. Әхмәт.

ЛЮ'ЛЬКА *и. сөйл.* **1.** Эшчеләрне, төзү материалларын һ. б. югарыга күтәрү өчен асылмалы басма.

2. Мотоцикл коляскасы; бишек.

ЛЮ'МЕН *и. физ.* Яктылык агышын үлчәү берәмлеге. *Әгәр бер люмен яктылык агышы бер берәмлек зурлыгындагы мәйдан өстенә тигез төшсә, ул мәйданның яктыртылуы бер берәмлеккә тигез була.* Физика.

ЛЮМИНА'Л *и. махс.* Йокысызлыктан һәм нерв системасының кайбер башка авыруларына каршы кулланыла торган дару.

ЛЮМИНЕСЦЕ'НТ *с. физ.* Люминесценциягә нигезләнгән. *Чардакларга яшерелгән люминесцент лампалар күзләрне талдырмый торган тигез яктылык бирәчәкләр.* Соц. Тат.

ЛЮМИНЕСЦЕ'НЦИЯ *и. физ.* Газ, сыеклык яки каты җисемнең, җылылык нурлары чыгармыйча, салкын яктылык нурларын чәчүе. *Люминесценция күренешләре.*

ЛЮМИНЕСЦИРЛАНУ *ф. физ.* Салкын яктылык бирү, люминесценция бирү сәләтенә ия булу. *Академик Вавилов бу лампаларның эчке өслеген люминесцирланучы матдәләр белән капларга тәкъдим итә.* Физика.

ЛЮМИНОФОР *и. махс.* Яктылык тәэсирендә люминесцирланучы матдә.

ЛЮ'МПЕН *и. сөйл. к.* люмпен-пролетариат. *Ни өчен соң [Җәгъфәр] шундый өтек люмпен кыяфәтендә?* А. Расих.

ЛЮ'МПЕН-ПРОЛЕТАРИАТ *и.* Бер-берсенә капмакаршы булган сыйныфлар яшәгән җәмгыятьтә үзләренең сыйнфый йөзләрен югалткан кешеләр катлавы (сукбайлар, хәерчеләр һ. б.). *Капитализмга хас булган конкуренция нәтиҗәсендә буржуа сыйныфының бер өлеше банкротлыкка чыга, бөлгенлеккә төшә һәм люмпен-пролетариатка әверелә.* М. Абдрахманов.

ЛЮНЕТ *и.* 1. *хәрби. иск.* Алдында тирән озын чокыр булган, туфрактан өелгән бер-ике валдан гыйбарәт кыр ныгытмасы.

2. *махс.* Гөмбәз эчендә, ишек яки тәрәзә өстендә көймә сыман уем.

ЛЮПИН *и.* Кузаклылар семьялыгыннан яшел ашлама; шулай ук терлек өчен азык итеп файдаланыла һәм декоратив үсемлек буларак үстерелә торган үлән үсемлек. *Люпин чәчүлекләре. Люпин орлыклары.* □ *Күпьеллык люпин бик зур һәм куе куак булып үсә.* Йорт эшләре.

ЛЮ'СТРА *и.* Берничә лампа яки шәмдәл куелып, бизәкләп эшләнгән асылмалы яктырту әсбабы. *Түшәмгә асылган зур люстраны [кабызса], бик артык кискен якты булачак.* Г. Ибраһимов.

ЛЮСТРИН *и.* Ялтыравыклы юка йон яки ярым йон тукыма. *Люстрин пальто.*

ЛЮТЕРАН *и.* Лютеран динендәге, лютеран динен тоткан кеше.

Лютеран дине — *к.* лютеранлык.

ЛЮТЕРАНЛЫК *и.* Протестант диненең XVI йөздә Мартин Лютер өйрәтмәсе нигезендә барлыкка килгән бер тармагы.

ЛЮФА *и.* 1. Кабакчалар семьялыгыннан көньякта үсә торган, зур кыярга охшаш җимешле бакча үсемлеге. *Моңа мисал итеп мунчада мунчала урынына кулланыла торган люфа җимешен күрсәтергә мөмкин.* Робинзон эзл.

2. Шул үсемлекнең киптерелгән җепселле җимешеннән ясалган болыт (губка).

ЛЮФТ-КЛОЗЕТ *и.* Җылы бәдрәф. *Люфт-клозетның базын, су үтми торган итеп, кирпечтән яки бетоннан ясыйлар.* Йорт эшләре.

ЛЮЦЕ'РНА *и.* Кузаклылар семьялыгыннан терлек өчен азык итеп кулланыла торган үлән үсемлек.

ЛЯ *и. муз.* Музыка гаммасының алтынчы авазы; шул авазны белдерә торган нота. *Ля нотасы.*

ЛЯ'МКА *и.* 1. Авыр әйберләрне тартып алып бару яки күтәреп ташу өчен кулбашка салына яисә киелә торган, күннән яки ныклы тукымадан ясалган киң каеш. *Казаклар шаярудан туктадылар, лямкаларын иңбашы аркылы киеп, төзәтенә-төзәтенә диңгез ягасына җыелдылар.* Ш. Камал. *Култык асларыннан тарттырып камыт сыман әйбер белән лямка кигән --- бер төркем кешеләрнең бөгелә-сыгыла нидидер авыр нәрсә тартып барганлыклары күренде.* М. Гали.

2. *сөйл.* Киемне күтәртеп тору өчен кулбаш аша төшкән тасма. *Сарафан лямкасы.*

ЛЯ'ПИС *и.* Төссез кристалл порошок (медицинада тәндәге яраны, инфекция кергән урынны дәвалау, йогышсызландыру өчен кулланыла). *Ляпис таякчыгы. Яраны ляпис белән яндыру.*

ЛЯ'ПИС-ЛАЗУ'РЬ *и. к.* лазурит.

ЛЯ'ПСУС *и. сөйл.* Тупас, мәгънәсез хата; аянычлы хата. *Ляпсус җибәрү.*

ЛЯФ *и. иск. к.* лаф. *Теге кяфер батыры әллә нинди ляфлар белән мактана башлаган икән, Гали батыр аның колагыннан тотып һавага аткан.* Г. Тукай.

ЛЯХ *и.* 1. *иск. к.* ләх I. *Анатолий кычкырып „Тарас Бульба"ны укый. --- Татарларны бик мәсхәрәләп телгә алган җирләрне Натолька сикертеп уза я, татар диясе урынга, лях (поляк) дип укып китә.* И. Гази.

2. Силезиянең бер өлешендә һәм Моравиянең төньяк-көнчыгышында яши торган берничә чех этнографик төркеменең гомуми атамасы.

ЛӘ *кис. к.* ла (бу кисәкчә нечкә авазлы сүзләрдән соң килә). *Беразга гына тынып калган урман, әйтерсең лә, балалар белән бергә уйнады.* Г. Минский. *Мендем дә лә тауларның башына, Язулар да яздым ташына.* Җыр.

ЛӘБАСА *кис.* Сөйләмдә белдерелгән фикернең әүтәлеген (раслауны, инкяр итүне, сорауны, гөманны һ. б.) көчәйтү өчен кулланыла. [*Ибраһим:*] *Дни, соң мин сиңа алай ачуланырлык бер сүз дә әйтмәдем ләбаса.* Г. Камал. *Кунак ашы кара-каршы булырга тиеш ләбаса.* Ә. Еники. || Сөйләмнең экспрессивлыгын, хискә тәэсир көчен арттыра. [*Бәдри:*] *Әйт [әм] ләбаса сиңа, ут яктысында укый алмыйм дип.* М. Фәйзи.

ЛӘББӘЙКӘ *хәб. функ.* 1. „Боерыкны, әмерне үтәргә әзермен" дигән мәгънәне белдерә („тыңлыйм", „баш өстә" дигән сүзләргә туры килә). [*Җиһанша:*] *Ләббәйкә, тәкъсир... Сез ни теләсәгез, шул булыр.* К. Тинчурин.

2. „Рәхим итегез" дигән мәгънәне белдерә. *„Ләббәйкә" дигән кебек, бер кулын күкрәк өстенә куеп чалкан яткан [ирең] ящь сабыйлар йокысы белән рәхәтләнеп йоклый булыр.* Ш. Камал.

ЛӘВАЗИМ *и. иск. кит.* Бурыч, вазифа. *Советлар власте бу яшьләрне Кызыл Армия гаммәсенә иң якын тора торган ләвазимнәр өчен хәзерләде.* Ф. Әмирхан. *Поп Архипов поплык ләвазименнән чыгарылган.* Урал.

ЛӘВӘШ *и.* 1. Эченә ит, тары ярмасы һ. б. ш. нәрсәләр яки йөзем салып пешерелгән бәлеш. *Ләвәшләрнең иң күп янган берсен Нәгыймә карчык көндезге чәй янына кисте.* Ш. Камал.

2. *диал.* Күзикмәк, юка. [*Хаҗиморат*]. *Хәзер генә табадан төшкән коймакларны, ләвәшләрне --- кунаклар алдына таратып, чәй ясый башлады.* Г. Ибраһимов.

3. *диал.* Катлы паштет.

ЛӘГУ *и. иск.* Буш сүз, мәгънәсез сүз; ялгыш, хата.— *Югыйсә, без бу көннән игъланны туктатабыз вә, башсыз чыккан игъланнарны ләгу санап, акчаны суд белән кире сорыйбыз.* Г. Тукай.

ЛӘГЪНӘТ *и.* 1. Бик каты гаепләү, каргау, көчле нәфрәт белдерү сүзе; каһәр. [*Зөһрә:*] *Бу газаплар өчен кемгә миңа ләгънәт диярга!* Ф. Бурнаш. [*Байтирәк:*] *Минем үткән көннәремдә кызыксынырлык бернәрсә дә юк. Алар минем исемә төшсә, барлык дөньясына ләгънәт әйтәсем килә.* Т. Гыйззәт. || *хәб. функ.* Кемне дә булса нәфрәт белән читкә кагу, бик каты гаепләү; аңа карата көчле нәфрәт белдерү. *Җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләр, сезгә мең ләгънәт!* Г. Тукай. [*Карт:*] *Ләгънәт сиңа! Чык! Күземә күренмә!* Ш. Камал.

2. *гади с. тирг.* Яратмаган, күрәлмаган кеше яки берәр нәрсә турында. *Курка, ләгънәт, куркып чәчен йолка, Чукмар белән маңгаена суккан этнекедәй, күзе акая.* Ф. Кәрим. [*Имәли:*] *Өй түгел иде*

бит ул, кабер иде. Ничек котылырга белми идем ләгънәттән. М. Әмир. || Берәр кешегә яки берәр нәрсәгә җиңелчә шелтәләп әйтелгән сүз. [*Кыз:*] *Калтыранасың ич, әллә Сарбай ләгънәт куркыттымы?* Г. Әпсәләмов. | *с. мәгъ. Шул ләгънәт кызны кулга төшерми куймам дип, бик килешсез ант вә шарт итүләре --- Галинең күңеленнән килеп үттеләр.* М. Гафури.

3. *ы. мәгъ. сөйл.* Бик каты ачулану, нәфрәт, шелтәләүне, канәгатьсезлек һ. б. ш. хисләрне белдерү өчен кулланыла. *Охранка мине үзенең мәкерле, хәйләле тозакларына эләктереп куймасын тагы, ләгънәт.* Г. Ибраһимов.— *Ике атнадан артык инде, ләгънәт. Сентябрь кергәч коя башлаган иде, һаман туктар сәгате юк.* Г. Әпсәләмов.

Ләгънәт итү — *к.* ләгънәтләү. *Кузгал, уян, ләгънәт ителгән коллар һәм ачлар дөньясы.* Интернационал.

◇ **Ләгънәт камыты** — 1) дини мифологиядә: Иблис оҗмахтан сөрелгәндә, алланың аны ләгънәтләве; Иблис өстенә төшкән, бервакытта да кичерелми торган гөнаһ-хурлык тамгасы.— *Мәлгунь Иблис, мине инкяр итмә! Ләгънәт камытын тиздән киярсең.* М. Гафури; 2) *күч.* туктаусыз башкарырга кирәк булган бик авыр, газаплы эш турында. **Ләгънәт(ләр) уку** — *к.* ләгънәтләү.— *Ачуымны кемнән алырга белмичә, укуына, дөньясына, алласына ләгънәт укып, --- кан йотып, --- авылга кайтып егылдым.* Г. Ибраһимов. **Ләгънәт ору** *юг.*— *к.* ләгънәт(ләр) уку. *Менә әле генә ләгънәт орып, Таштым, шаштым, куптым давылдай.* Ш. Бабич. *Күпкә бармас тарлык, сабыр ит, ирек, Ләгънәт орма, бизмә дөньядан.* Н. Думави. **Ләгънәт төшкән** — бик каты гаепләнә торган, нәфрәт уята торган, күрәлмаган, ләгънәтләнгән. [*Нәгыймә:*] *Ул бит өйләнмәкче булып йөри.* [*Галимә:*] *Дй ләгънәт төшкән нәрсә! --- Кем дигәнне алмакчы була?* Ш. Камал. [*Исәнбай:*] *Ләгънәт төшкән мәдрәсә гадәте... Һәрбер яңа килгән шәкертне газаплап интектерү гореф-гадәт булып әверелгән.* Т. Гыйззәт. **Ләгънәт суксын (төшсен, суккыры, төшкере)** — 1) хорафат карашларда: „зарар килсен, зыян булсын“ дигән мәгънәне белдерә. [*Мавия:*] *Алланың ләгънәте төшсен авылдашыңа! Син, абзый, авылдаш булсаң, аны азрак акылга өйрәт.* М. Фәйзи; 2) бик каты ачулануны, нәфрәтләнүне белдерә. [*Хөсәен:*] *Тукта, юньсез. --- Тукта, ләгънәт төшкере.* Ф. Бурнаш.

ЛӘГЪНӘТЛЕ *с. сөйл.* Бик каты гаепләнә торган, нәфрәт уята торган, ләгънәтләнгән. [*Әхтәм:*] *Менә миндә шул мирзаның ләгънәтле каннары бар дип, [ул] үзен үзе хурлый башлый.* Г. Ибраһимов.

ЛӘГЪНӘТЛӘҮ *ф. сөйл.* **1.** Кемне дә булса бик каты гаепләп шелтәләү, каһәрләү, кемгә дә булса явыз теләк теләү. *Шәмсетдин хәзрәт күз төпләрен сөртә-сөртә --- хатыннарын ләгънәтләгән.* Э. Касыймов. || Кемне дә булса читкә кагу, үз итмәү.— *Аллаһы тәгалә үзенең яратмаган бәндәсен, озын гомер биреп, күп гөнаһларга дучар итү белән ләгънәтли, дигәннәр борынгы китаплар.* З. Бәширн.

2. Бик каты хурлау, тиргәү, тәнкыйтьләү; канәгатьсезлек белдерү. *Менә шулай ләгънәтләде язучы иске кануннарны, иске гадәтләрне һәм диннең, руханиларның алдавын фаш итте.* Г. Халит.

ЛӘГЫЙНЬ *с.* **1.** Ләгънәтләнгән, ләгънәт-хурлык тамгасы белән тамгаланган; мәлгунь. *Бер заман иңмәс борын иблис ләгыйнь, Торды инсан ал да гөл дә, син дә мин.* Ш. Бабич. [*Хаҗи:*] *Дйе, иблис ләгыйньнең атабыз Адәм[не] җәннәттән чыгаруын сөйли.* Ш. Камал.

2. *күч.* Нәфрәт уята торган, әшәке, начар. [*Кабил:*] *Гүя миңа ләгыйнь көчләр Ерактан кулларын өстемә төртеп сузалар.* Һ. Такташ.

3. *и. мәгъ. хурл.* Әшәке кеше, начар кеше; нәфрәт тудыра торган кеше. [*Әхмәтҗан:*] *Каһәр сукканнар, бәдбәхетләр, ләгыйньнәр, мәңгелек игелек күрмәгез.* Г. Камал. [*Хәнифә:*] *Яәҗүж-мәәҗүҗ токымыдыр бу фашист дигән ләгыйньнәр.* Р. Ишморат. || *кер. сүз функ. сөйл.* Хурлау, тиргәү яки җиңелчә шелтәләүне һ. б. ш. белдерә. [*Мингаян песигә:*] *Әнә ничек күзләрен мутландырып карый, ләгыйнь.* С. Рафиков. [*Имәли:*] *Мин сезне, акыллы гына сүзләр сөйләшеп килгәч, аеклар дип торам тагын, ләгыйньнәр.* М. Әмир.

ЛӘГЫЛЬ *и. иск.* Ал яки кызыл төстәге кыйммәтле таш. *Йөземнәр көнгә каршы ялтырыйлар, ләгыль вә якуттай.* Г. Тукай. || *с. мәгъ.* Шуңардан эшләнгән, ясалган; шул асылташ куеп ясалган. *Ләгыль йөзек.*

ЛӘГӘН *и.* Гадәттә түгәрәк һәм сай зур калай савыт. *Ауса да, тәгәрәсә дә ләгәннеке бер тавыш.* Мәкаль. *Җолкынбай, кулына кечкенәрәк кенә җиз ләгән, комган алып, түгәрәк табындагыларның шул утырган хәлләрендә, мәҗлес уртасында йөртеп, кулларына су сала башлады.* Г. Ибраһимов.

ЛӘЖ *рәв. диал.* Җәелеп, арка белән (яту турында). *Шул яшькә җиткәннән соң да әле әбиләренең ашап-эчеп, ләж ятып кына тормыйча, кеше төсле бөтенесе белән кызыксынуы аңлашылмый яшьләргә.* Азат хатын. || *күч.* Гамьсез рәвештә, бернәрсә дә эшләмичә. *Ләж яту.* **Ләж калу** *диал.* — көлтәне сукканда тоташ кисәк сугылмыйча калу.

ЛӘЖБӘЮ *ф. диал.* Җәелү, җәелеп утыру яки җәелеп яту.

ЛӘЗЗӘТ *и.* **1.** Рәхәтлек, рәхәт, кәеф, хозур. *Шул көн ул башлап тормышның ләззәтен татыды.* Г. Ибраһимов. *Җәйге иртәдә кояш белән бергә торып, Агыйделдә су коенуның ләззәтен аңларлык культуралы кыз бу якка кайдан килеп чыккан!* М. Әмир. || Нинди дә булса берәр эшне уңышлы башкарудан, үтәүдән табылган канәгатьлек хисе. *Ул — Нуруллинның һәр хәрәкәтен күзәтеп тора, аның нәрсә теләгәнен күз карашыннан ук тотып ала, аны шунда ук үтәргә ашыга һәм шул үтәүдән чамасыз ләззәт, шатлык таба.* А. Шамов. *Көрәштә генә [кеше] үзенә ләззәт таба ала.* Г. Коләхметов. *Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде.* Г. Кутуй. || Куанычлы хис, шатлыклы хис, сөенечле тойгы. *Аның елавы Гарифның --- күңелен әллә нинди билгесез бер шатлык, эч өзгеч моң һәм ләззәт белән тутыра иде.* Ш. Камал. *Миңнурый, --- шул җырны яңадан ишеткән кебек, тирән ләззәткә чумып күзләрен йомды.* Г. Әпсәләмов.

2. Тәм. *Ашау ләззәтен тәгам алдыңа килмәс борын ук, авыз суларыңны йота-йота, бөтен эчең белән тоеп торасың.* Ә. Еники. [*Кешеләр*] *бик тәмләп, ләззәтен белеп тәмәке тарталар һәм ашыкмый гына сөйләшәләр.* А. Шамов.

ЛӘЗЗӘТЛЕ *с.* 1. Ләззәт (1 мәгъ.) бирә торган, рәхәтлек бирә торган. *Ләззәтле хыял. Ләззәтле хис.* □ *Сөләйманның бөтен тәне буйлап ләззәтле калтырау йөгерде.* К. Тинчурин. *Илсөяр --- киләчәк турындагы ләззәтле уйларга чумды.* Г. Гобәй.

2. *сөйл.* Татлы, тәмле. *Ләззәтле ширбәт.* □ *Менә бу чәй никадәр ләззәтле.* М. Гафури.

ЛӘЗЗӘТЛЕЛЕК *и.* Рәхәтлек; ләззәтле булу. *Кошлар тавышыннан, һаваның сафлыгыннан, аның хуш ислелегеннән, дөньяның матурлыгыннан, яшәүнең ләззәтлелегеннән исергән идем мин.* А. Шамов.

ЛӘЗЗӘТЛӘНДЕРҮ *ф.* Ләззәт (1 мәгъ.) бирү, рәхәтлек бирү. [*Тукай*] *табигать тормышының кешелек өчен булган тиңсез, ләззәтләндергеч агышын да җырлый.* Г. Халит.

ЛӘЗЗӘТЛӘНҮ *ф.* Ләззәт (1 мәгъ.) табу, рәхәтлек кичерү. *Алар болай гына очрашканда да рәхәтланеп, ләззәтләнеп сөйләшәләр.* А. Шамов. [*Разия*], *үзен борынгы юнан һәйкәлләре белән чагыштырып, сәгатьләрчә ләззәтләнә иде.* Г. Ибраһимов.

ЛӘЗЗӘТСЕЗ *с.* 1. Ләззәте (1 мәгъ.) булмаган, ләззәт бирми торган. *Аларның --- тәмсез, ләззәтсез шигырьләрен ник мактамыйлар?!* Г. Тукай.

2. *сөйл.* Тәмсез, тәме булмаган.— [*Шакмаклы*] *шикәр ләззәтсез була, анасы, юлга аны алмам; ватканны бирерсең.* Ф. Әмирхан.

ЛӘЗЗӘТСЕЗЛЕК *и.* Ләззәтсез булу. *Сыек чәйнең ләззәтсезлеге.*

ЛӘЗЗӘТСЕЗЛӘНДЕРҮ *ф.* Ләззәтен югалту, ләззәтен бетерү. *Һичберәүгә бер генә тиен дә файда итмәгән, бөтен милләтнең тормышын харап итеп ләззәтсезләндергән гадәт-гореф вә искелек булсалар, шуларның күбесе нәкъ әүвәлге килешләрендә үк дәвам иттеләр вә итәләр.* Ф. Әмирхан.

ЛӘЗЗӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* Ләззәте югалу, ләззәте бетү.

ЛӘЗИЗ *с. иск.* Ләззәтле, тәмле, татлы. *Ләзиз ашамлыклар.* □ *Бу җиһанда --- ләзиз нигъмәтләр --- күптер.* Бәет.

ЛӘИМ *и. иск.* Саран; түбән җанлы кеше. *Көрәш угрында ар, тал, тирлә, имгән; Өмет итмә булышмакны ләимнән.* Г. Тукай.

ЛӘИМЛӘНҮ *ф. иск.* Саранлану.

ЛӘЙ *кис.* Кайбер халык җырларында текстны көйнең ритмикасына туры китерү өчен кулланыла торган, мәгънәсе булмаган сүз. *Йөгереп китәрдәй булам, Кайтып җитәрдәй булам Көзге ачы җилләрдә ләй Туган-үскән илләргә.* Җыр. *Дус-иш белән бергә эш иткәндә, Теләкләргә тизрәк ләй җитәрбез.* Җыр.

ЛӘЙЛӘ *с. иск.* Кичке, төнге. *Ләйлә ай.* □ — *Сән җаныем өчен бән йөримен ләйлә* [*йокыларымны*] *калдырып.* Г. Тукай.

ЛӘЙСӘН *и.* Яз көне беренче тапкыр вак кына сибәләп яуган җылы яңгыр. *Ләйсән тамчысы.* □ *Җир дымлы, күрәсең, таң алдыннан гына яңгыр явып үткән. Беренче яңгыр. Картлар аны ләйсән — шифалы яңгыр диләр.* И. Салахов.

Ләйсән яңгыр(ы) — *к.* ләйсән. *Ләйсән яңгыр бары бер кат ява, Шуңар, ахры, тансык, сөйкемле.* М. Җәлил. *Кар китеп бетәр-бетмәстә яуган җылы ләйсән яңгыр, ихтимал, язның иң ямьле тантанасыдыр.* Р. Төхфәтуллин.

ЛӘКАП, ЛӘКАБ *и. иск.* 1. Кушамат. *Бу —„җылкычы ата“ ләкабе белән йөртелә торган Юныс карт иде.* Г. Ибраһимов. || Титул. *Һәм шушы зур хезмәте өчен әллә нинди зур бәһа дә сорамый, бары князь ләкабе бирелү белән канәгатьләнәчәклеген бәян итә.* Ф. Әмирхан.

2. *диал.* Мәкаль.

ЛӘКАТӘ *и. иск.* Табылдык, тапкан әйбер турында әйтелә. [*Вәли:*] *Ләкатә таптым, ләкатә, --- урласам ләкатә кычкырмас идем.* Т. Гыйззәт.

ЛӘ!КИН *терк.* 1. Тезмә кушма җөмләләрдә икенче җөмләнең башында килеп, аны беренчесенә капма-каршы куя. *Тар һәм кечкенә тәрәзә турысында өстәл шикелле бернәрсә булган, ләкин кемнәрдер аның такталарын каерып алып киткәннәр.* Г. Әпсәләмов. *Тагын нәрсәдер әйтергә теләгән иде, ләкин ул турыда аңа карчыкка сөйләү оят тоелды.* А. Шамов. [*Бибкәй:*] *Күзегез белән күргәч ышанырсыз, ләкин соң булыр.* Т. Гыйззәт. || Җөмләнең аерым тиндәш кисәкләрен бер-берсенә каршы кую өчен кулланыла. *Газиз Сараның кулын үпмәкче була, ләкин бу вакытта агачлар арасыннан Фатыйма белән Ибраһимның чыкканын күреп үпми.* Ф. Әмирхан. *Кәли --- ышандырырлык берәр сүз әйтергә уйлады, ләкин килешле сүз таба алмады.* Г. Гобәй.

2. Беренче җөмләдә әйтелгән фикергә каршы фикерне белдерә торган гади яки кушма җөмлә башында килә. *Аның әүвәлдә үземә матур күренгән һәммә җирен ямьсезгә чыгардым һәм, шулай итеп, үзүземне беркадәр юаттым. Ләкин, ачуым басыла төшкәч, болай дип уйлавымның дөрес түгел икәнен үзем дә бик яхшы аңладым.* Ф. Әмирхан. *Араларында бер егет балык аулый. Ләкин тоттым дигәндә генә балыклары шуып чыга.* Н. Исәнбәт. || Шундый ук җөмләләрне өлешчә чикләп каршы куя. *Габдулла, бик теләсә, олы гына кешеләр белән дә шигырь әйтешә ала, ләкин бу әйтешүләрдә җиңеп чыгар өчен бернәрсә җитми икән.* Ә. Фәйзи.

3. Бер-берсенә каршы куела торган җөмләләрнең һәм җөмлә кисәкләренең кире шарт бәйләнешендә булуын күрсәтә: мәгънәсе „шулай да“, „шуңа карамастан“ сүзләренә туры килә. *Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе, Ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе.* Г. Тукай. *Дөрес, мин яшь идем әле. Ләкин әдәбият укытучыбызның дәресне күңелле итеп алып баруы аркасында күп кенә әсәрләр белән танышырга өлгергән идем.* Г. Кутуй. *Гафиятнең башында йөз төрле уй, ләкин аңа карап үткен чалгысы тукталып тормый аның: чаж-чож һаман чаба да чаба ул.* И. Гази.

4. Алда килгән җөмләне аның бер сүзе кабатланган икенче җөмләгә каршы кую яки чикләү мәгънәсен көчәйтү өчен кулланыла. [*Г. Камалның*] *кайбер элеккерәк язган әсәрләрендә аз-маз „гарәп, фарсы һәм госманлы сүзләре күренгәләсә дә, ләкин ул сүзләрнең күпчелеге шул әсәр язылганда халыкның сөйләү теленә кергән сүзләр генә.* М. Гали.

5. Иярченле кушма җөмләләрдә: иярчен җөмлә башында кайбер алмашлыклар, ияртүче теркәгечләр яки мөнәсәбәтле сүзләр белән килеп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйләүдә катнаша. *Ләкин никадәр генә* [*Маһибикә*] *көлсә дә, күңел канәгатьләнми.* М. Әмир.

6. Башка кайбер каршы куючы теркәгечләр белән бергә килеп, каршы кую мәгънәсен көчәйтә. [*Хөснетдин:*] *Мин анысына каршы килмим. Әмма ләкин миңа акча кирәк.* Ш. Камал.

7. Ымлыклар, модаль сүзләр белән бергә килеп, аларның мәгънәсен һәм алдагы җөмләләргә каршы куюны көчәйтә. *Ләкин ah! Нинди зур ялган! Ышанмыйм мин моңар бер дә!* Н. Исәнбәт. *Ләкин һәйһат* [*үкенеч*]*! Болар бар да төш, бар да буш хыял гына иде.* Ш. Мөхәммәдев.

8. *и. мәгъ.* Нәрсәгә дә булса комачаулаучы берәр төрле хәл; каршылык. [*Мавия:*] *ул „ләкин“нең аръягын бик яхшы аңлыйм, Бәкер абзый. Ничек тә мин аны хәл итәргә тырышырмын.* М. Фәйзи.

ЛӘКЛӘК *и.* Озын аяклы, озын туры томшыклы зур кош. *Ак ләкләк. Кара ләкләк.* □ *Су буенда тартар тынган. Ләкләк киткән.* Ә. Ерикәй.

Ләкләк борын *ирон.*— 1) озын борын; 2) озын борынлы кеше. [*Ирбулат:*] *Бая да әле Зәкия ләкләк борын дигәч гарьләнеп үлә язды.* Р. Ишморат.

ЛӘКЛӘКЧӘЛӘР *и.* Ләкләкләр семьялыгы (челән, ләкләк һәм ибис керә).

ЛӘКШӘ *и. диал.* Токмач. *Эткә ләкшә салма, үләксә сал.* Н. Исәнбәт.

ЛӘКЪЛӘКА *и. иск., сөйл. к.* ләкәтә.

Ләкъләка сату *иск., сөйл.* — *к.* ләкәтә сугу. *Муса әфәнде минем белән ләкъләка сатарга аз бушагач, бу кабинетта үземә үзем уңайсызлык та сизгәч, минем көннәр, табигый, тагы авырая төштеләр.* Г. Тукай.

ЛӘКӘН *и. диал.* Агачның төбе-тамыры. *Ләкән чыгару.*

ЛӘКӘС *и. диал.* 1. Сөйкемсез кеше. || Юан кеше. 2. *с. мәгъ.* Ялкау.

ЛӘКӘТӘ *и. диал.* Гәп, әңгәмә, сөйләшү. *Һәммәсенең бияләйдәй колак торган, Ләкәтәләр куера төшкән әүвәлгедән.* Ф. Бурнаш.

Ләкәтә сугу (сату) — юк-бар нәрсә турында сөйләшү, гәпләшү; ләүтит сату. *Урамны чыккач та, култык астына калын портфелен кыстырган бер бәндә туктатып, беркавым ләкәтә сатып торды.* М. Хәсәнов.

ЛӘЛӘ *и. сөйл. к.* лалә. *Без, --- 200 төрдән артык күз явын алырлык лалә чәчәкләреннән бер читкә китеп, шикәр чөгендере игүдәге тәжрибә белән танышырга булдык.* Соц. Тат.

ЛӘМ I *и.* 1. Сулыклар (елга, буа, күл-диңгезләр) төбендәге бик кечкенә минераль һәм органик кисәкчәләрдән гыйбарәт утырма, дуен. [*Капитан:*] *Кичәге яңгырдан соң ташыган инеш басулардан алып килгән ләмне шушында өеп калдырган.* С. Сабиров. *Яр буйлап килә-килә балчыкка, ләмгә буялып беттек.* Ш. Рәкыйпов. *Алар ләм, елан агулары белән дәвалауның күп төрле юлларын белгәннәр.* Соц. Тат.

2. *диал. к.* лай I (1 мәгъ.).

ЛӘМ II *и. иск.* Татарларда гарәп графикасы гамәлдә чактагы әлифбада „л" хәрефенең исеме. [*Габделкаюм:*] *Әби, син мине укырга өйрәткәндә: „ләм" кисәү агачы шикелле була, дип өйрәткән идең.* М. Гали.

ЛӘМ III: **ләм ялтәфит** *иск.* — ис китмәү, әйләнеп тә карамау, илтифат итмәү турында. *Минем хәлне белгән иптәшләр дә миңа күп даруның исемен әйтеп карадылар. Әмма мин ләм ялтәфит.* Г. Тукай. *Көлделәр: куркытган әйбер буш икән! Тордылар ләм ялтәфит.* Ш. Бабич.

ЛӘМКӘ *и. сөйл. к.* лямка. *Карт Каспийның Сөзәк итәгендә Балыкчылар ләмкә тартканнар. Ләмкә тәнне кискән.* М. Җәлил.

Ләмкә тарту — 1) электә: нинди дә булса судноны, мәсәлән баржаны, яр читеннән ләмкә ярдәмендә тартып алып бару. [*Көй*] *Идел буенда ләмкә тартучылар зарын зарлый.* И. Рәмиев; 2) интегеп авыр эш эшләү, берәр авыр эш белән җәфа чигү.

ЛӘМЛЕ *с.* Ләме I (1, 2 мәгъ.) күп булган; ләм I (1 мәгъ.) утырган. *Елгаңың ләмле төбе.*

ЛӘМЛӘНҮ *ф.* 1. Ләм I (1 мәгъ.) утыру, ләм җыелу (су төбенә). *Елганың төбе ләмләнү.*

2. *диал.* Ләм I (2 мәгъ.) үсү, ләм белән капланы. *Су ләмләнгән.*

ЛӘМ-МИМ *рәв. сөйл.* Бер сүз дә, бернәрсә дә әйтмәү, сөйләмәү турында. *Миңсылу --- ләм-мим эндәшми утырды.* Ш. Камал. [*Низами:*] *Хуҗамнан ләм-мим дә ишеткәнем юк.* С. Җәләл. | *хәб. функ.* [*Перико:*] *Тик нәрсә алу турында аңа ләм-мим. Аңлашыламы?* А. Әхмәт.

Ләм-мим дәшмәү, ләм-мим сүз әйтмәү (катмау) — бер сүз дә әйтмәү, бер сүз дә дәшмәү; бөтенләй сөйләшмәү. *Башлыклар бу юлы да бүген нәрсә буласы, солдатларны кайда алып барулары хакында ләм-мим сүз әйтмәделәр.* М. Гафури. *Алар юлның калган өлешен бер-беренә ләм-мим сүз катмыйча бардылар.* А. Расих.

ЛӘП *аваз ияр. к.* ләп-ләп I.

Ләп итү — *к.* ләп-ләп итү. *Аягың ләп итсә, авызың чәп итәр.* Мәкаль.

ЛӘПЕК *и. диал.* Баткак, пычрак. [*Мәфтуха*] *тездән кара ләпек ярып коры җиргә үрмәләгәндә дә, юлар кешедәй, кет-кет көлеп үрмәләде.* Г. Мөхәммәтшин. *Без, пычрак юлда ләпек ярып, шат, көр күңел белән, батырларча аның артыннан атладык.* Н. Фәттах.

ЛӘПЕЛДӘТҮ *ф. сөйл.* Иреннәрне бер-беренә тидереп һ. б. ш. юллар белән үзенә бер аерым тавыш барлыкка китерү; чәпелдәтү.

ЛӘПЕЛДӘҮ *ф. сөйл.* 1. Берәр предмет икенчесенә бәрелгәндә һ. б. ш. вакытта үзенә бертөрле тавышавазлар барлыкка килү.

2. *күч.* Хәрәкәт итү, хәрәкәттә булу (берәр эш башкару турында). *Аягың ләпелдәп торса, Авызың чәпелдәп торыр.* Мәкаль.

ЛӘПЕРӘ *и. сөйл.* Махау авыруы. *Аның маңгаенда, ефәк кебек чәчләре арасында күренеп калган кутыр, шиксез, ләперә зәхмәте иде.* Аң.

ЛӘПЕС *и. сөйл. к.* ляпис. *Кына һәм басма, ләпес һәм перекись белән буялган чәчләр!* Ш. Хөсәенов.

ЛӘПЕШ *и. диал.* Кыш уртасында яки иртә язда карны эретә торган җылы һава.

ЛӘП-ЛӘП I *аваз ияр.* Берәр предмет икенче бер предметка җиңелчә бәрелгәндә һ. б. ш. очракларда барлыкка килгән тавышны белдерә. *Ләп-ләп бәрелү.*

Ләп-ләп итү — 1) шундый тавышка охшаган аваз-лар чыгару. *Самарның ат аягы ләп-ләп итеп кәефне китереп бара торган асфальт урамы белән вокзалга юнәлдек.* Г. Тукай; 2) *күч.* хәрәкәт итү, хәрәкәттә булу (берәр төрле эш башкару турында).

ЛӘП-ЛӘП II *и. сөйл.* Суган кыягының бер очын берничәгә ярып, шул ягыннан авызга кабып өргән вакытта бөтерелеп ясалган алка. *Минһаҗ бакчадагы түтәлдән суган кыягы өзеп алды. Аны авызына кабып, яр буенда „ләп-ләп" ясап йөрде.* М. Шәрифуллин.

ЛӘП-ЛӨП *аваз ияр. к.* ләп-ләп I. *Ләп-лөп килү.*

ЛӘПШЕК *с.* 1. *сөйл. к.* лапшык.

2. *диал.* Җәенке, яньчек. *Ләпшек борын.*

ЛӘПШЕРДЕК *с. сөйл.* Ләпшердәгән, ләпшердәгән хәлгә килгән.

ЛӘПШЕРДӘҮ *ф. сөйл. к.* ләшпердәү.

ЛӘПШЕРӘҮ *ф. сөйл. к.* ләпшердәү. *Көпчәк шины ләпшерәп төшкән, тәмам бушаган.* А. Шамов.

ЛӘПШӘЮ *ф. диал.* Җәенкеләнү, ямьшәю, яньчекләнү. *Тиздән ак чалма урынына ләпшәеп беткән картуз --- кыячәген уйлап,* [*Вахит*] *калтыранып китте.* М. Гафури. [*Солдатлар*] *ләпшәйгән фуражкаларын күтәреп башларын кашыйлар.* А. Таһиров.

ЛӘПШҮ *ф. диал.* Жебеп төшү, мәлҗерәү. [*Шәмәк:*] *Тарт дим, тарт!* [*Сафа:*] *Әйдә, әйдә, ләпшемә, агай-әне!* К. Тинчурин.

ЛӘСА *кис. сөйл. к.* ләбаса. *Елмайганда балкып китә ләса авызында алтын теше дә.* З. Мансур.

ЛӘТАФӘТ *и. иск. кит.* Гүзәллек, матурлык. *Бу ике шигырьдә нинди ләтафәт, нинди нәфасәт, нинди поэзия!* Г. Тукай. *Заман үткән саен, табигать хәле алышына вә борынгы ләтафәт югала барып, хәзер бу җирләр бик яланғач вә төсмерсез булып калган иде.* Ш. Камал.

ЛӘТЧӘ *и.* 1. Сусарлар семьялыгыннан гәүдәсе нечкә һәм сыгылмалы булган кечкенә ерткыч хайван. [*Гөлхәят:*] *Уналты чебешне ләтчә буып үтергән.*

Каз. утл. *Сайгак астыннан чыгып, шаулап йөрергә башлады Барча тычканнар, комаклар, ас вә әрләп, ләтчәләр.* Ш. Бабич.

2. *күч. сөйл. хурл.* Ирләр белән чытлыкланырга яратучы, ирләр белән бутала торган яки усал хатын-кыз турында. [*Бәдигылҗамал:*] *Ни эшләсәм эшләрмен, Ибраһимнан бу ләтчәсен аерттырырмын.* Г. Камал.

ЛӘТЧӘЛЕК *и. күч. сөйл.* Ирләр белән чытлыклану, ирләр тирәсендә чуалу яки бик усал булу. [*Гаҗби:*] *Шул үзенең ләтчәлеге белән ирен эчәргә сабыштырды инде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЛӘТЫЙФ *с. иск.* Гүзәл, матур, нәфис. *Хәзер аның ләтыйф хыялы гына бүлмә эчендә почмактан почмакка күчеп йөри.* Ш. Камал. *Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф булып, - - - мөкаддәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр.* Г. Тукай. || Йомшак, яхшы. *Ләтыйф җил.*

ЛӘТЫЙФЛЕК *и. иск. к.* ләтафәт.

ЛӘФЫЗ *и. иск.* Сүз. *Телим, ташлап кирәкмәгән вак сүзләрне, „Сөям, җаным" ләфызларына ашыын.* Г. Тукай. *Бу — ләфызны саклап калу өчен мәгънәне оттырырга әзер тору.* Ф. Әмирхан.

ЛӘФЫЗПӘРӘСТЛЕК *и. иск. кит.* Хәрефкә ябышып яту, коры формализм.

ЛӘХ I *и. иск.* Поляк.

ЛӘХ II *рәв. сөйл.* Лаякыл, бөтенләй (исерү турында). *Ләх исерек.*

Ләх булу — лаякыл исерү, бик нык исерү. [*Үги ата*] *буйга җитеп килгән кызны кияүгә бирү, туй ясау һәм шул туйда ләх булганчы бер эчү турында хыяллана.* Ш. Хөсәенов.

ЛӘХЕТ *и.* Мәет кую өчен кабер төбенең бер як кырыеннан эчкә таба чокып ясалган урын, уем. [*Әбинең*] *гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар.* Ә. Еники. [*Шәрифҗан:*] *Ничек, Миңнулла абзый, ләхет уярга вакыт җитмиме әле?* И. Гази. || Гомумән кабер. *Җәмилә инде тыныч ләхеткә барачак, туфрак Җәмиләне кочагына алып, мәрхәмәтле һәм шәфкатьле аналар кебек кочып саклаячак.* М. Гафури.

ЛӘХЗӘ *и. иск. кит.* Күз ачып йомганчы үткән вакыт арасы. *Бу я бер ләхзә, бер күз ачып йому, я бөтен бер гасыр, озын, бик озын гомер сөргән бер адәмнең бөтен гомере иде.* Ф. Әмирхан. *Алды тынлык дөньяны, шул ләхзәдә шылт иткән бер тавыш юк сахрада!* Ш. Бабич.

ЛӘХӘҮЛӘ *и. иск. дини. сөйл.* Ислам динендәге „бөтенесе дә алладан, бөтенесе алла ихтыярында" дигән мәгънәдәге доганың татарча үзенә бер төрле кыскартылмасы. *Җимерелеп китсә авыр ташлар, „ләхәүлә" дип дога укыйлар.* М. Гафури. *Үткән-сүткән кешеләр бу шомлы урманны ләхәүләләрен укып кичәләр.* А. Гыйләҗев.

ЛӘЧ *рәв. диал. к.* лач II.

ЛӘЧКЕЛДӘҮ *ф. диал. к.* лычкылдау.

ЛӘЧ-ЛӘЧ *аваз ияр. к.* лач-лоч. *Лач-лач сагыз чәйнәп нәүбәт көтеп торучы кызларның, киленнәрнең чәч үргечләренә таккан тәңкәләре бер-берсенә бәрелеп чылтырыйлар.* М. Галәү.

Ләчкелдәп тору — *к.* лычкылдап тору.

ЛӘЧМӘ *рәв. диал. к.* лычма. *Дәүләтшин, - - - ник килгәненә үкенеп, бата-чума кайтып китә. Өсте ләчмә су була егетнең.* И. Гази.

ЛӘЧТИТ *и. сөйл.* Юк-бар сүзләр, буш сүзләр, сафсата.

Ләчтит сату — юк-бар сүзләр сөйләшү, сафсата сату. *Хатын-кызлар, ирләре өйдә юклыктан файдаланып, эчке өйләрендә ләчтит сатып утырдылар булса кирәк, ишек алдында, чоланда берсе дә күренмәде.* М. Әмир. [*Вәлиев:*] *Пожар лапасында ләчтит сатып ятудан башка берни белмисез.* С. Рафиков.

ЛӘЧТӘ *рәв. диал. к.* ләч.

ЛӘШКӘР *и. иск., кит.* Гаскәр. *Мәхшәр кубып, Килделәр диңгез кебек ләшкәр булып.* Ш. Бабич.

ЛӘШПЕРДЕК *с. сөйл. к.* лапшырдык.

ЛӘШПЕРДӘҮ *ф. сөйл.* **1.** Мускуллар (тән) сәлперәю, йомшару, эластиклыгын югалту.— *Ул ишанның дүрт хатыны булган, ди. Иң өлкәне инде ләшпердәп төшкән бер карчык, ди.* Г. Ибраһимов.

2. Шиңү, пәҗү; сулу (үсемлекләр турында). *Гөл ләшпердәү.*

3. Сыгылмалылыгын югалту; йомшару, бушап калу (мәсәлән, шин).

ЛӘШТЕРДӘТҮ *ф. сөйл. к.* лаштырдату. *Бала, - - - яланаякка элдерткән каталарын ләштердәтә-ләштердәтә, түбән очка таба йөгерде.* Г. Минский.

ЛӘШТЕРДӘҮ *ф. сөйл. к.* лаштырдау. *Ләштерди торган галошлар.*

ЛӘШТЕР-ЛӘШТЕР *аваз ияр. к.* лаштыр-лоштыр. [*Гәрәй*], *аягына кигән ямаулы итек башын ләштер-ләштер өстерәп, пароход пристанена таба төшеп китте.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ЛӘШТЕР-ЛӨШТЕР *аваз ияр. к.* лаштыр-лоштыр. *Каталарын сөйрәп, ләштер-лөштер китеп бара.* Б. Рәхмәт.

ЛӘЯКАТЬ *и. иск., кит.* Лаеклылык, лаеклы булу.

ЛӘЯКАТЬЛЕ *с. иск., кит.* Лаеклы, тиешле. [*Бай*] *кыяфәте, сөйләшкән сүзе илә адәмнән хисап ителсә дә, һәркемгә тигезгән җәбере вә мәлгуньлеге илә иблис - - - ләкабен алырга ләякатьле иде.* Ш. Мөхәммәдев.

ЛӘҮ *и. иск.*, **1.** Кәлтә, аждаһа.

2. *иск.* Төрки халыкларда һәр елы берәр хайван исеме белән аталган унике еллык циклның бишенче ел исеме. *12 ел исемнәре: тычкан, сыер, бәрес, куян, ләү, елан, елкы, куй, мичин, тавык, эт, дуңгыз.* Н. Исәнбәт.

ЛӘҮКӘ *и.* Мунчада чабыну өчен биек сәке. [*Сәмигуллин:*] *Шушы азаплардан бер котылып, өемә исән-сау гына кайтып керсәм, бер ай буе хатыннан мунча яктырып, ләүкәдән төшми чабынып ятыр идем.* М. Гали. *Мунча ягып,* [*Сөләйманны*] *эссе ләүкәгә мәңгереп, тәнен куй мае белән удылар.* К. Тинчурин.

ЛӘҮХӘ *и. иск.* **1.** Картина, күренеш. *Җил дә әллә нигә зарланган төсле була, күңелгә куркынычлы нәрсәләрнең ләүхә вә сурәтен төшерә иде.* М. Гафури.

2. Вывеска; плакат. *Капка башында ящел ләүхә тора, Анда - - - ошбу сүзләр укыла...* Г. Тукай. *Каршыдагы ишекнең уң ягында сүзләре кызыл белән чигелгән рамкалы бер ләүхә.* М. Фәйзи.

ЛӘҮХЕЛМӘХФҮЗ *и. иск.* Язмыш, тәкъдир. [*Ишан:*] *Ләүхелмәхфүздә безгә кардәш булырга язган булса, аны бозып булмас.* К. Тинчурин.

ЛӘҖБЕРӘЮ *ф. диал. к.* ләшпердәү (*3* мәгъ.). *Чернозубов карават астыннан бушап, ләҗберәеп калган күн чемоданын тартып чыгарды.* Ә. Маликов.

ЛӘҢГЕЛДЕК *с.* Ләңгелдәп өрүче, нечкә тавыш белән өрә торган, чәнгелдек. *Бүре басар Алабай ырылдап куркытса, башка вакытта капка астыннан өргән ләңгелдек көчеккә дә сәлам биреп йөрисең, диләр.* А. Гыйләҗев.

ЛӘҢГЕЛДӘҮ *ф. сөйл.* **1.** Нечкә тавыш белән өрү, чәнгелдәү.— *Кара* [*бу этне*], *ничек ләңгелди.* Р. Батуллин.

2. *күч. гади с.* Әрләү, хурлау; гайбәт сату. *Тик, култыклашып, көпә-көндез кинотеатр янына барырга ярамас, --- Луизаны күрсәләр, ләңгелдәп туймаслар.* А. Гыйләҗев.

ЛӘҢКӘ *и. сөйл.* Нечкә тавыш белән чәңгелдәп өрә торган кечкенә эт.

Ләңкә көчек — *к.* ләнкә. *Сөләйман --- наборщик алдында, арыслан янында торган ләңкә көчек төсле, кечкенә һәм зәгыйфь итеп хис итте үзен.* К. Тинчурин.

ЛӘҢ-ЛӘҢ *аваз ияр.* Ләңгелдәп өргән эт тавышын белдерә. *Ләң-ләң өрү.* □ [*Кәрлә көчек:*] *Ләң-ләң, баерга киткән Мәфтуха тәтәй бөлеп кайта түгелме?* А. Әхмәт.

ЛӘҺҖӘ *и. иск., кит.* Тел, диалект (шивә). *И мөхәррир, --- Кертмә бер чит ләһҗәдән „хәреф“ [грамматик чара] ләһҗәбез тәртибенә.* Дәрдмәнд.

ЛӨГАТЬ *и. иск.* 1. Сүз, сөйләм. *„Чеңләшә“ кәлимәсе безнең иске лөгатебез булырга кирәк.* Г. Тукай.

2. Сүзлек. *Лөгать китабы.* □ *Хәлимәнең „комган“ дигән сүзне әүвәл мәртәбә ишетүе булганлыктан, „Иске татар сүзләре“ исемле лөгать китабын карамаенча бер җавап та бирә алмады.* Ф. Әмирхан. *Габделвәли үзенә аерым русча-төрекчә лөгать дәфтәре ясады һәм Габдулладан русча өйрәнергә тотынды.* Ә. Фәйзи.

ЛӨГАТЬЛЕК *и.* Сүзлектә яки энциклопедиядә аңлатма бирелә яки тәрҗемә ителә торган барлык сүзләр; шул сүзләрнең исемлеге.

ЛӨГАТЬЧЕ *и. иск.* 1. Сүзлекләр төзүче, лексикограф.

2. Сүзлекләр бастырып чыгаручы.

ЛӨЗҮМ *и. иск.* Кирәклек, тиешлек. *Шуның өчен алар --- җәмгыяте хәйрия ясау лөзүмен күптән хис итмәктә иде.* Г. Тукай.

Лөзүм күрү (табу) — тиеш дип табу, кирәк дип санау. *Хәмидә тыныч вакытында каенагасыннан кача торган иде. Мондый [гадәттән тыш] эшләр булып киткәч, яшеренеп торырга лөзүм күрмәде.* М. Гафури. *Ул турыда сөйләргә лөзүм күрмичә, фәкать хәтергә килгән берникадәр [фикерләрне] генә язам.* Ф. Әмирхан.

ЛӨЗҮМЛЕ *с. иск.* Кирәкле, тиешле. *Лөзүмле тәнкыйть.*

ЛӨЗҮМЛЕЛЕК *и. иск.* Кирәклек, тиешлек, зарурлык. *Бу берләшмәкнең никадәр кирәклеген, никадәр лөзүмлелеген аңлату өчен мин ушбу мисалны китерәм.* Г. Тукай.

ЛӨФХӘТӘН *рәв. иск., кит.* Бөтенләй, тулысынча. *Лөфхәтән ияру.*

ЛӨЭЛӨЭ *и. иск., кит.* Энже. *Шул миңа сер чишмәсеннән лөэлөэ вә мәрҗан бирә.* Ш. Бабич.

ЛҮРТ-ЛҮРТ *обр. ияр. к.* лурт-лурт. *Лүрт-лүрт чабу.*

ЛҮС-ЛҮС *обр. ияр. к.* лус-лус. *Лүс-лүс юыртып бару.*

М

М Татар алфавитында унөченче хәреф.

МАВЗОЛЕЙ *и.* Кабер өстенә төзелгән зур корылма; кабер өсте һәйкәле. *Ленин мавзолее.* □ [*Болгар җирендә*] *зур мәчетләр, төрбәләр, мавзолейлар, руханилар өчен мәктәп-мәдрәсәләр киң төзелә башлый.* Каз. утл. *Дәһлидә мавзолей дүрт кырлы яссы ташлан гыйбарәт булса, Җабалпурда без зур һәм матур бина күрдек.* М. Мәхмүтов.

МАВР *и. тар.* Антик чорда һәм урта гасырларда: Төньяк Африка илләрендә (Мисырдан кала) яшәгән төп халыкның европача атамасы. || VIII гасырда, Европага үтеп, Пиреней ярымутравының зур өлешен яулап алган гарәпләрнең һәм алар белән Африкадан килгән бәрбәр кабиләләренең атамасы.

МАВРИТАН *с.* Мавританиягә (төньяк-көнбатыш Африканың борынгы атамасы) мөнәсәбәтле, мавританиягә караган. *Мавритан кабиләләре. Мавритан стиле.*

МАВЫГУ *ф.* **1.** Берәр нәрсә белән артык кызыксыну, шуның белән бирелеп шөгыльләнү. *Болынлыкта Фатыйма чәчәкләр белән мавыга башлады.* Г. Әпсәләмов. *Сәяси темаларга язылган әсәрләрне --- йотылып, әкият укыганнан битәр мавыгып укыдык.* М. Әмир. || Нәрсәгә дә булса тулысынча бирелү, шуның белән генә мәшгуль булу. *Уенга мавыгу. Сүзгә мавыгу.* □ *Д мин, басуда эш белән мавыгып, күпме вакыт үткәнен дә сизми калдым.* Р. Ишморат. *Нургали җавап тапканчы тәмәке төрү белән мавыккан булды.* Ә. Еники. || Маташу, берәр нәрсә белән мәшгуль булу. *Нәсимә белән Хәмидә казаннар тирәсендә мавыгалар.* Ш. Камал.

2. *күч. сөйл.* Кемгә дә булса гашыйк булу, аның тирәсендә күп чуалу. [*Җәләл Миләүшәгә:*] *Син Корбый белән бик мавыгасың булырга кирәк, чибәр булудан бәхетле булу артыграк.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

МАВЫГУЧАН *с.* Нәрсәгә дә булса һәвәсләнеп, бик нык бирелеп китүчән. *Беренче яшьлек елларында кеше бик мавыгучан булса, төрле модалар йогынтысына да бик тиз бирелә.* М. Максуд.

МАВЫГУЧАНЛЫК *и.* Мавыгучан булу сыйфаты. *Музыка белән мавыгучанлык.*

МАВЫКЛАНУ *ф. сир. к.* мавыгу. *Сүзгә мавыкланы.* □ *— Хатип, син шул эшләреңне яратып, мавыкланып эшлисең.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Шул хуш тавышларга мавыкланып бара торгач, без пароход туктар өчен ясалган бик матур пристань күрдек.* Ф. Әмирхан.

МАВЫКТЫРГЫЧ *с.* Бик кызыклы, игътибарны нык җәлеп итә торган. *Габделвәли һаман да Габдулла белән бергә шигырьләр укый һәм әдәбият турында мавыктыргыч әңгәмәләр алып бара.* Ә. Фәйзи. *Күңелле, мавыктыргыч хезмәтнең болай тиз тәмамлануына Гарифулла көрсенеп куйды.* Э. Касыймов.

МАВЫКТЫРГЫЧЛЫ *с. сир. к.* мавыктыргыч. *— Миңа да берәр мавыктыргычлырак китап бир әле.* Каз. утл.

МАВЫКТЫРГЫЧЛЫК *и.* Мавыктыргыч булу сыйфаты. *Мавыктыргычлык әдәбият өчен начар нәрсәмени? Начар нәрсә түгел, бәхәсләшмибез. Әмма нинди мавыктыргычлык?* И. Нуруллин.

МАВЫКТЫРУ *ф.* **1.** Кызыксындыру, кызыктырып шөгыльләндерү. *Нәрсә белән генә [Наҗияне] мавыктырырга соң дип, Мостафин еш кына баш вата иде.* Ә. Еники.

2. Кызыксындыру, игътибарны нык җәлеп итү. *Хәзер Илдарны иң мавыктырган нәрсә җәнлекләр булды.* Г. Гобәй. || Үзенә карату, тарту; буйсындыру, әсир итү. [*Наилә*] *рояль янына утыра. --- Уңышлы алынган аккордлар аны уенга мавыктырып алып кереп китәләр.* Р. Ишморат. [*Хәятны*] *шундук икенче, өченче кешеләр мавыктыра башлыйлар.* Ф. Хөсни.

МАГ *и.* Борынгы Көнчыгыш илләрендә һәртөрле гыйбадәтләрне, дини йолаларны үтәүче һәм күрәзәлек итү белән шөгыльләнүче дин башлыгы; жрец.

МАГАЗИН *и.* **1.** Зур кибет. *Китап магазины.* □ *Гөлсем апа, Казанга килеп, йомыш-юлларын йөреп чыккач та уенчык магазинына керде.* Г. Гобәй.

2. Аппаратларда, приборда, ату коралларында бертөрле берничә әйбер салу өчен хезмәт итә торган җайланма (тартма, диск, көпшә һ. б. ш.). *Вася --- икс винтовка да тапкан. Магазиннарында патроннары да бар.* А. Шамов.

МАГАРА'ҖА *и.* Һиндстанда югары князь титулы; шул титулга ия булган кеше. *Менә укалы чалмасына энҗе-мәрҗән һәм кыйммәтле ташлар тезгән, кулына кәкре кылыч тоткан --- ниндидер магараҗаның рәсеме.* М. Мәхмүтов.

МАГИЗМ *и. кит.* Сихерчелек, күрәзәчелек, багучылык.

МА'ГИК *с.* Магиягә бәйләнешле. *Магик көч.*

◇ **Магик квадрат** — һәр юлы, һәр баганасы һәм һәр диагональләре буенча суммасы бер үк сан чыгарлык цифрлы бүлемнәрдән торган квадрат.

МАГИСТР *и.* **1.** Чит илләрнең кайберләрендә һәм революциягә кадәрге Россиядә гыйльми дәрәҗә; шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Медицина һәм политехника институтларына керү өчен бик зур конкурс үтәргә туры килә. Аларда укып, магистр дәрәҗәсе алу шулай ук катлаулы хәл.* Каз. утл.

2. *тар.* Урта гасырларда рухани-рыцарьлар ордены башлыгының титулы; шул титулны алган кеше.

МАГИСТРАЛЬ *и.* **1.** Аралашу юлларында (мәсәлән, тимер юлда, су һәм һава юлында) төп, үзәк, зур юл. *Немецларның һәм финнарның берләшкән төньяк группа гаскәрләренең төп бурычы --- Киров магистрален кисү һәм Мурманск шәһәрен алу иде.*

Г. Әпсәләмов. *Идел буе бит — су магистрале.* Г. Бәширов. || Хәрәкәт бик зур булган үзәк урам. *Алар бара торган магистральгә тигез дүрткел итеп кискән гранит ташы җәелгән.* Ш. Маннур.

2. Электр, телеграф, телефон, канализация һәм су, нефть үткәргечләр челтәрендә төп труба яки төп кабель. *Җир асты магистральләре — зур диаметрлы трубалар буенча аккан нефть елгасы - - - ГДР га кадәр барып җиткән инде.* М. Хәсәнов.

3. *с. мәгъ.* Магистральгә (1, 2 мәгъ.) бәйләнешле; төп, үзәк, әһәмиятле. *Магистраль канал. Магистраль кан юлы.* □ *Безгә әдәбиятның зур юлы, магистраль юлы турында һич онытырга ярамый.* Г. Ахунов.

МАГИСТРАНТ *и.* Элекке Россиядә һәм кайбер чит илләрдә магистрлык дәрәҗәсенә диссертация якларга хәзерләнүче кеше.

МАГИСТРАТ *и.* 1. Кайбер Көнбатыш Европа илләрендә шәһәр идарәсе; муниципалитет. || Россиядә, Петр I тарафыннан кертелеп, 1885 елга кадәр эшләп килгән һәм суд-администрация, салым җыю эшләре алып барган сайлаулы шәһәр идарәсе.

2. *тар.* Борынгы Римда консул, трибун, претор һ. б. ш. кебек югары хезмәт урыны; шул хезмәтне башкаручы кеше.

МАГИСТРАТУ'РА *и. тар.* 1. Кайбер Көнбатыш Европа илләрендә һәм революциягә кадәрге Россиядә — суд ведомствосы. || *җый.* Судья вазифасын үтәүчеләр; судьялар.

2. *җый.* Борынгы Римда югары дәүләт хезмәте; шул хезмәт урынындагы кешеләр төркеме.

МАГИ'СТРЛЫК *и.* 1. Магистр (1 мәгъ.) дәрәҗәсе. *Магистрлыкка диссертация яклау.*

2. Магистр (2 мәгъ.) власте, магистр идарәсе.

МА'ГИЯ *и.* 1. Хорафатларга ышану буенча, табигать законнарына каршы килә торган күренешләр тудырырга сәләтле серле ысуллар җыелмасы; сихер-челек.

2. *күч.* Кемгә дә булса тәэсир итә, йогынты ясый торган гадәттән тыш көч.

МА'ГМА *и. геол.* Җирнең үтә тирән катламыннан күтәрелә торган силикат составлы уттай кызган сыек масса (суынып каткан вакытта вулканик тау токымнары хасил итә). *Миллион еллар элек биредә [Таймырда] мәхшәр булган: 30—40 километр җир астыннан - - - ут сыман матдә — магма бәреп чыккан.* Каз. утл.

МА'ГМАЛЫ *с.* Магмага мөнәсәбәте булган; магма катнашкан, магмадан торган. *Магмалы тау токымнары.*

МАГМА'ТИК *с. к.* магмалы. *Магматик тау токымнары — җир шарының геологик үткәнен чагылдыра торган көзге.* Каз. утл. || Магма сыман; кызып эрегән, сыек. *Токымның магматик хәле.*

МАГНАТ *и.* 1. Кайбер Европа илләрендә (бигрәк тә феодаль крепостнойлык чорындагы Польшада һәм Венгриядә) эре җир биләүче, алпавыт. *Польша магнатлары.*

2. Эре капиталист. — *Америка финанс магнатлары, һөҗүмгә күчүне шарт итеп, Вакытлы хөкүмәткә зур суммада заемнар бирделәр.* Т. Гыйззәт. *Капиталның иң эре магнатлары еш кына буржуаз илләрнең дәүләтләрендә иң әһәмиятле постларны билиләр.* Политэкономия.

МАГНЕЗИТ *и.* Магний карбонатыннан гыйбарәт ак яки саргылт төстәге минерал (утка чыдамлы материал буларак файдаланыла). — *Сез [мичтән] бер яктан корычны алып бетеругә, алар, икенче яктан магнезит сибеп, тутыра да башладылар.* Н. Исәнбәт.

МАГНЕЗИТЛЫ *с.* Составында магнезит булган. *Магнезитлы кирпеч.*

МАГНЕ'ЗИЯ *и.* Магний оксиды яки тозыннан гыйбарәт ак җиңел порошок (медицинада кулланыла). — *Николай Максимович, сезгә бүген ике доза магнезия, — ди сестра, палатадан чыга-чыга.* Г. Әпсәләмов.

МАГНЕ'ЗИЯЛЕ *и.* Составында магнезия булган. *Магнезияле цемент.*

МАГНЕТИЗМ *и.* Кайбер җисемнәрнең (магнитларның, электр корылмаларының) икенче җисемнәрне үзләренә тарту яки үзләреннән читкә этәрү үзлеге. *Җир магнетизмы.* □ *Дөньяда телепатия, магнетизм дигән гажәеп күренешләр - - - бар.* Г. Мөхәммәтшин.

МАГНЕ'ТИК *с.* Магнетизмга мөнәсәбәте булган. *Магнетик күренешләр.*

МАГНЕТИТ *и.* Составында тимер булган һәм магнитка хас үзлекле каты, кара минерал; магнитлы тимерташ.

МАГНЕ'ТО *и. тех.* Эчке янулы двигательләрдә, очкын барлыкка китереп, ягулыкны кабызып җибәрү өчен хезмәт итә торган электромагнитлы прибор. *[Айдар һәм Хәйдәрев], икесе бергәләп, трактурга көндезге техник карауны үткәрделәр — магнето да үз урынында, очкыннар да чыгып тора.* Ф. Хөсни.

МА'ГНИЙ *и.* Күз чагылдыргыч ак ялкын белән яна торган җиңел, чүкелүгә тиз бирелүчән көмеш сыман ак металл. *Магний тозы эремәсе. Магний сульфаты.* □ *Бер секунд эчендә, магний яктысында күренеп киткән кебек, Мөнирәнең күз алдына мәктәп көннәре - - - килеп басты.* Г. Әпсәләмов.

МАГНИЙЛЫ *с.* Магнийдан торган яки составында магний булган. *Магнийлы эретмәләр. Магнийлы ашламалар.*

МАГНИТ *и. физ.* Тимер һәм корыч предметларны үзенә тарту яки читкә этәрү сәләтенә ия булган тимер рудасы яки корыч кисәге. *Тимер кисәкләре магнитка сырышкан кебек, егетләр Якуб тирәсенә өелештеләр.* И. Гази. || *күч.* Үзенә тарту, җәлеп итү көченә ия булган кем-нәрсә турында. *[Вәли Халисәгә:] Тәки синең турыда уйлап йөрим. Әллә магнитың бар инде.* С. Рафиков.

Магнит авышуы *физ.* — географик һәм магнит меридианнары арасындагы почмак. **Магнит аномалиясе** *физ.* — җир магнетизмы элементларының бүленешендә магнитлы руда токымнары ятмасына (магнитлы тимерташка) бәйләнешле рәвештә барлыкка килә торган урындагы авышлык — кабул ителгән нормадан тайпылыш. **Магнит давылы** *физ.* — Җир шары магнетизмының кинәт, кыска вакытка тиз һәм законча-лыксыз үзгәреше (Кояшта кара таплар барлыкка килү белән бәйләнгән). **Магнит иелүе** *физ.* — Җирнең магнит кыры көчләре юнәлеше белән горизонт яссылыгы арасында хасил була торган почмак. **Магнит кыры** *физ.* — даими магнит яки токлы үткәргеч тирәсендә аларның магнитлануга сәләтле җисемнәргә тәэсир итү көче сизелерлек пространство. *Җирнең магнит кыры.* **Магнит күчәре** *физ.* — магнит полюслары ноктaларын тоташтыра дип фараз ителгән туры сызык. **Магнит меридианы** *физ.*— Җир өстенең билгеле ноктасында магнит угы күчәре аша үтә дип фараз ителгән вертикаль яссылык. **Магнит угы** *физ.* — вертикаль күчәр өстендә иркен рәвештә әйләнеп торырлык итеп эшләнгән, бер очы белән һәрвакыт төньякны күрсәтә торган озынча ромб сыман юка һәм нечкә магнит пластинка; компасның төп детале. **Магнит экваторы** *физ.* — Җирнең магнит кыры авышлыгы

нольгә тигез нокталарын тоташтыра дип уйланган йомык сызык.

МАГНИ'ТИК *с.* Магнитка бәйләнешле, магнитка мөнәсәбәте булган. *Магнитик индукция. Токның магнитик тәэсире.*

МАГНИТЛАНУ *ф.* Магнит үзлекләре хасил булу, үзендә магнит үзлекләре барлыкка килү. *Тимернең магнитлануы.* □ *Баскан җирдән китеп булмый. Китеп булмый—Баскан җирем магнитланган.* Э. Мөэминова.

МАГНИТЛАУ *ф.* Нинди дә булса җисемдә магнит үзлекләре булдыру. *Энә очын магнитлау.* || *күч.* Кызыктырып үзенә тарту, җәлеп итү. *Яңа калалар авыл яшьләрен үзләренә магнитлыйлар.* А. Гыйләҗев.

МАГНИТЛЫ *с.* Магнит үзлекләренә ия булган. *Магнитлы җисемнәр. Магнитлы антенна.* □ *Урал! Магнитлы тауларың Күтәрде коммуна байрагын.* Ф. Кәрим. || Магнит үзлекләренә бәйләнешле. *Магнитлы тирбәну.* || *күч. хәб. функ.* Кемне дә булса үзенә тарту, җәлеп итү турында. *— Безгә кунак бер килеп китсә, аннан гел киләсе килеп кенә тора. Магнитлы ул безнең җәйләү.* С. Рафиков.

Магнитлы тимерташ — *к.* магнетит.

МАГНИТЛЫЛЫК *и.* Магнитлы булу. *Җисемнең магнитлылык үзлекләре.*

МАГНИТО- Кушма сүзләрдә „магнит", „магнитлы" мәгънәләрен белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: **магнитограмма, магнитооптика, магнитодинамика.**

МАГНИТО'ГРАФ *и.* Җирнең магнит кыры үзгәрешләрен әзлекле рәвештә язып, теркәп бара торган прибор.

МАГНИТО'ЛОГ *и. махс.* Магнит күренешләрен өйрәнүче галим — белгеч.

МАГНИТО'МЕТР *и. махс.* Магнит кырының көчәнешлелеген үлчи торган прибор.

МАГНИТОФОН *и. махс.* Электромагнит ярдәмендә тавышны язып алу һәм аны яңадан сөйләтү, ишеттерү аппараты. *Маннурның --- кичәдә сөйләгән кереш сүзен Казаннан, радиодан килгән корреспондент хәтта магнитофон лентасына язып алды.* М. Хәсәнов.

МАГНОЛИТ *и.* Магнезияле цемент, пычкы чүбе, асбест сүсе һ. б. катнашмалардан торган ясалма төзү материалы (идән, бүлмә такталары, тәрәзә төпләре һәм төрле плитәләр хәзерләү өчен кулланыла).

МАГНО'ЛИЯ *и. бот.* Хуш исле ак яки ал төстәге эре чәчәкле һәм эре яфраклы мәңге яшел агач яки куак. *Магнолияләр сезгә сөт шикелле Ак чәчәкләр бүләк итәрләр.* М. Җәлил.

МАДАМ *и.* Франциядә, революциягә кадәрге Россиядә һәм тагын кайбер илләрдә хатын кешегә мөрәҗәгать итү сүзе (гадәттә исем яки фамилиягә кушып әйтелә); ханым. *Мин кергәч тә, мадам бик тынычсыз гына сурәттә: — Теге татарлар күренмәделәрме? — дип сорады.* Ф. Әмирхан.

МАДАПОЛАМ *и.* Гадәттә эчке кием тегәргә китә торган ак киже-мамык тукыма. *Мендәр тышлык мадаполам алу.* || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Мадаполам күлмәк.*

МАДЕМУАЗЕЛЬ, МАДМУАЗЕЛЬ *и.* Франциядә, революциягә кадәрге Россиядә һәм кайбер илләрдә кыз кешегә мөрәҗәгать итү сүзе (гадәттә фамилияләренә яки исемнәренә кушып әйтелә); туташ. [*Эмигрантларның ашханәләрендә*] *идән себерүче, кашыксавыт юучы — киләчәктә генераль ша булырга хәзерләнгән мадемуазельләр һәм стажлы карт генераль шалар.* Г. Гали.

МАДЕ'РА *и.* Куәтле виноград аракысының бер төре. [*Өстәлдә*] *коньяк, мадера, сыра бутылкалары тезелгән.* Ш. Мөхәммәдев.

МАДО'ННА *и.* Католикларда: алла анасының атамасы; шулай ук аның скульптурасы яки сынлы сурәте. || *күч.* Илаһи матурлык, сафлык, тыйнаклыкның гәүдәләнеше булган хатын-кыз турында. — [*Профессор*] *менә шушы мадоннага урын әзерли, — дип,* [*Сәлах*] *Гөлшаһидәгә дә ташланып алды.* Г. Әпсәләмов. [*Муса, фоторәсемне дминәгә күрсәтеп:*] *Кил әле, кара, син анда мадонналар кебек нинди мәһабәт.* Н. Исәнбәт.

МАДРИГАЛ *и.* 1. *әд.* Гадәттә берәр ханымга багышлап язылган кечкенә лирик мактау шигыре.

2. *иск.* Ялагайлы мактау сүзләре, комплимент. *Мадригаллар әйтү.*

МАДЬЯР *и. к.* венгр. *Митингка, Оренбург мөселман батальоныннан башка, мадьярлардан җыелган „эмигрантлар легионы" --- катнашты.* Ш. Усманов. [*Каршы якта*] *мадьяр офицерларының чиккән якалы курткалары күренә.* Ф. Хөсни.

МАДЬЯ'РЧА *рәв.* Мадьяр (венгр) телендә.

МАЁВКА *и.* Революциягә кадәр Россиядә эшчеләрнең Беренче Май көнне шәһәр читенә чыгып үткәрә торган яшерен җыелышлары. [*Дим буенда*] *уенкөлке күләгәсе астында митинг — маевка башлана.* Х. Садрый. *1906 елда Уральск читендәге Чаган елгасы буенда маевка була. Бу маевкада Тукай да катнаша.* С. Шакир.

МАЁВКАЧЫ *и.* Маевкада катнашучы. *Маевкачыларны әзәрлекләү.*

МАЕМЛАТУ *ф. з-сыз. сөйл.* Артык күп яки артык майлы, баллы нәрсәләр ашаудан эч бозылу, күңел болгану турында. *Тулай торак күршесендәге конфет фабрикасына барып, --- туйганчы шоколад эремәсе эчәбез. Икенче көнне маемлата, ашыйсы килми.* Ш. Маннур.

МАЕМЛАУ *ф. сөйл.* Артык күп яки артык майлы, баллы нәрсәләр ашау сәбәпле эч бозылу, күңел болгану; үтләү. *Әни: — Конфеттан бернинди зарар да юк. Ашыйсыңмы тагын берне, Инсаф? — ди. Мин инде маемлап беткән булам, конфет-шикәрне күрәсем дә килми.* Г. Мөхәммәтшин. || *күч.* Бизү, тую. *Шулай көйләнеп китә Мостафинның эчке тормышы. --- Рәхәтләнә бир, маемлап кына китмә!* Ә. Еники. [*Карачәч — ханга:*] *Сезнең ул сараегызда йөзләрчә гүзәл хатыннарыгыз була торып та монда килүегез ач үзәктән булмас, булса да тук үзәктән булыр. Гәпкә боерылмасын, безнең кара халыкта моны маемлау дип атыйлар.* Н. Исәнбәт.

МАЕМСЫР *с. сөйл.* Керләнеп, каешланып каткан; майлаган сыман ялтырап торган. *Гөлшаһидә кухняны карап чыкты... Сөлгеләре керләнеп беткән, савыт-сабалары маемсыр.* Г. Әпсәләмов.

МАЕМСЫРАУ *ф. сөйл.* Керләнеп, каешланып, майлагандай ялтырап тору. *Бу — сакал-мыексыз маемсырап торган киң калын битле, кысык күзле бер казах иде.* Ә. Фәйзи.

МАЕМСЫРАУЛЫ *с. к.* маемсыр. *Маемсыраулы алъяпкыч. Маемсыраулы иреннәр.*

МАЖОР *и. муз.* Тавышлары зур һәм кече терцияле аккорд барлыкка китерә торган музыкаль лад; дәртле, күтәренке тавыш төсмерләре белән характерлана; *киресе:* минор. *Әкрен генә* [*баян*] *уйный башладым. --- Гадәттәгечә, салмак көйләрдән башлап, кыскарак көйләргә, аннары бию көйләренә, соңрак мажор ладка, тантаналы моңнарга тоташканымны Сафуан абый сикереп торгач аңладым.* Ә. Баян.

МАЖОРДОМ *и.* 1. *тар.* V—VIII гасырларда Франк дәүләтендә югары дәүләт хезмәтендәге кеше.

2. Барин йортында баш хезмәтче; дворецкий.

МАЖОРИТА'Р: мажоритар система *махс.* — күп кенә капиталистик илләрдә яшәп килә торган антидемократик сайлау системасы (бу система буенча,

билгеле бер округта күпчелекне алган партия кандидаты өчен бирелгән тавышлар гына исәпкә алына).

МАЖОРЛЫ *с.* Мажорга нигезләнгән. *Мажорлы гамма.*

МАЗА *и.* 1. Тынычлык. *Суның мазасы боз белән, Ашның тәме тоз белән.* Мәкаль. — *Шулар килгәннән бирле, юк тормышның мазасы, Шулар шомы аркасында ява бәла-казасы.* Т. Гыйззәт.

2. Кайгы, борчу, мәшәкать. *Йөздә бары мәгърур көлемсерәү, Уйдан ерак дөнья мазасы.* М. Җәлил. [*Прокурор*] *эшкә бар, үзем күзәтеп, белешеп торырмын дигән була. Күзәтә, пычагым, онытмандыр да инде! Мазасы бер Давыт кына иде, ди.* А. Гыйләҗев.

3. *күч.* Файда, мәгънә. — *Айдар абзый, сүз озайтуда маза юк. Кәҗарманны чыгарасызмы, юкмы?* Т. Гыйззәт.

◇ **Мазасын алу (җибәрү, китәрү)** — тынычсызлау, борчу, йөдәтү. *Бай белән кода булсаң, телләнеп мазаңны алыр, ярлы белән кода булсаң, теләнеп мазаңны алыр.* Мәкаль. **Маза китү** — 1) тынычсызлану, борчылу, йөдәү; тынычлык югалу. [*Гайшә Мостафага:*] *Бик мазаң китте, ахры; балабыз елаграк шул.* Ш. Камал; 2) тынычлык бетү. *Илнең мазасы киткән. Яу артыннан яу.* М. Госманов.

МАЗАЛАУ *ф. к.* мазасызлау. *Бабай бервакытта да сүгенми, ачуланмый иде. Берәребез аны бик артык мазалый башласа гына: — Кит әле моннан!.. — дип куя торган иде.* Г. Гали. *Без, һәрвакыт салынып төшеп мазалый торган киндер ыштанларны күтәрә-күтәрә, бер-беребезне узышып, тау астына тәгәрәдек.* Г. Бәширов.

МАЗАР I *и. иск.* 1. Кабер; зиннәтле кабер. *Үлегенә карап мазары, товарына карап базары.* Мәкаль.

2. *к.* мазарлык. *Балалы өй — базар, Баласыз өй — мазар.* Мәкаль.

МАЗАР II *и. диал.* 1. Билгесез бер урын яки юнәлеш турында. *Кай мазарыма киткәндер. Кай мазарыма куйганнардыр, һич таба алмыйм.*

2. Билгесез бер әйбер, нәрсә турында. *Әй, әни, күрсәң иде* [*аның*] *кармакларын; шундый шәпләр, аның калкавычлары да агачтан түгел, әллә ни бер мазар шунда.* З. Бәшири.

МАЗАР III *кис.* Исемнәргә (сирәк кенә фигыльләргә) ялганып парлы сүз ясый һәм билгесезлекне, чамалап әйтүне белдерә. *Кем белә, хәлфә, бәлки,* [*кода абыйның*] *кушаматы-мазарыдыр?* Ә. Фәйзи. *Аның өчен кирәк түгел киңәш-мазар, һич тәм тапмый кешеләрнең сүзләреннән.* М. Максуд.

МАЗАРЛЫК *и. иск.* Каберлек, зират. *Менә кинәт киселделәр саз кыллары, Өзелеп көе, тынып калды гармуннары, --- Мазарлыктай тынга калды табыннары.* Ф. Бурнаш.

МАЗАРСТАН *и. иск.* Каберлек, зират.

МАЗАСЫЗ *с.* 1. Тынычсыз, хәвефле, чуалышлы. *Габидулла бистәдәге мазасыз хәлләр өчен шәһәр түрәләренең борчылуын әйтеп сүз башлады.* Г. Минский.

2. Кайгысыз, борчусыз, мәшәкатьсез. *Һай бу яшь күңелне, тынгысыз һәм мазасыз бу дәртле йөрәкне!* Г. Бәширов.

МАЗАСЫЗЛАНУ *ф.* Тынычсызлану, борчылу. *Шундук, мазасызланып, яшь бала еламсыраргa тотынды.* Г. Бәширов.

МАЗАСЫЗЛАУ *ф.* Тынычсызлау, борчу, интектерү. *Төрле шикләр, шомлы уйлар* [*дхмәдине*] *өзлексез мазасызлап тордылар.* Г. Бәширов.

МАЗЛУМ *с. иск.* Изелгән, җәберләнгән; кимсетелгән. *Мазлум халык. Мазлум күңел.* □ *Дөдә җырлыйк мазлум милләтләрнең Көчлеләрдән күргән хурлыгын.* М. Гафури. *Сез авыр, мазлум вә изгеч бер хәлдә калдыгыз.* Г. Ибраһимов. || *и. мәгъ.* Изелгән, җәберләнгән, кимсетелгән кеше. *Күпме зарлансам, урын бар, мин каты мазлум менә: Хәл җыймыйм ел тәүлегендә ичмасам бер көн генә.* Г. Тукай.

МАЗЛУМӘ *и. иск.* Хатын-кызга карата әйтелә; *к.* мазлум. *Никадәр генә мазлумә булсалар да, авыл хатыннары, һәрвакыт эш белән мәшгуль булу сәбәпле, мәгънәви газап чигәргә бушамыйлар.* Ш. Әхмәдиев. — *Мазлумәләрне ул канҫызлар кулыннан коткарырга тырышырга кирәк.* Ф. Әмирхан.

МАЗОК *и. мед.* Микроскоп аркылы карап тикшерү өчен, авыруның борыныннан, тамагыннан һ. б. алына торган лайлалы сыекча.

МАЗУ'РКА *и.* 1. Полякларның дәртле милли биюе. *Полька, мазурка, тустепларны биегәннән соң, „Көзге хыяллар" вальсы башланганда,* [*залда*] *ут сүнде.* И. Туктар.

2. Шул биюгә язылган музыка әсәре.

МАЗУТ *и.* Нефтьтән керосин, бензин, газолинны аерып алганнан соң калган куе сыекча. *Майлау мазуты. Ягулык мазуты.* □ [*Земснарядның машиналар бүлегеннән*] *машина мае, мазут исе белән катнаш җылы һава бөркелә.* Г. Әпсәләмов.

МАЗУТЛАУ *ф.* 1. Мазут белән каплау, буяу, мазут сеңдерү (нәрсәгә дә булса). || Мазутка буяу, пычрату; мазут таплары тидерү.

МАЗУТЛЫ *с.* Мазутка буялган, мазут сеңгән. *Бистәдә мазутлы бишмәттән дә күп нәрсә юк.* Г. Минский. *Юксына йөрәгем Гомернең шул чагын, Дагалы итеген, Мазутлы бушлатын.* Х. Туфан. || Мазут салынган. *Мазутлы чиләк.*

МАЗЫЙ *и. иск.* Үткән заман. *Баштан кичкән хәлләр берәм-берәм мазыйның караңгы пәрдәсе артына кереп югала.* Г. Ибраһимов.

МАЗЬ *и. сөйл.* 1. Техник майлау әйбере; *к.* май 4. [*Газчылар*] *тагын гөр-гөр сөйләшергә тотындылар. „Менә бу җирдә күбекләнә, кызганма мазеңны, сыла!"* И. Гази.

2. Тәнгә, ярага сөртә торган куе май — дару; *к.* май 5. *Врач бармакны әйләндереп-тулгандырып караганнан соң: — Төзәлүгә таба бара, зарарлы әйбер юк, — диде һәм фельдшерга ниндидер мазь сөртергә һәм яңадан ураргa кушты.* Ш. Камал.

МАИЛ *с. иск.* 1. Һәвәс, оста, маһир. *Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык.* Г. Тукай.

2. *диал.* Тартым, сыман, оҳшаш. *Чиягә маил.*

МАИС *и.* 1. *к.* кукуруз. *Ашны консерва тартмасына салып өләшәләр. Бик сыек булганга, күтәреп кенә әчәбез. Икенчегә — ботка. Анысы маистан.* И. Гази.

2. *с. мәгъ.* Маиска мөнәсәбәтле. *Маис чәчүлекләре. Маис кыры.* || Маистан хәзерләнгән. *Маис боткасы. Маис крахмалы.*

МАЙ I *и.* 1. Хайван сөтеннән (сөт өстен, каймакны язып) алына торган туклыклы матдә. *Ак май. Сары май. Май язу.* □ *Хәйруш хатыны майда гына борчак коймаклары пешерде.* Х. Садрый. *Сөттә — саулык, майда — бәрәкәт, иттә — куәт.* Әйтем. || *с. мәгъ.* Май хәзерләүгә, җитештерүгә бәйләнешле. *Май заводы.*

2. Хайван тәнендә ит белән тире арасында яки әчәкләр тышында була торган май сыман ак катлам; шуннан әретелгән һәм ашамлык хәзерләү өчен тотыла (яки төрле техник һәм башка максатлар өчен дә файдаланыла) торган матдә. *Елкы мае. Каз мае. Балык мае.* □ *Уникенче ротаның солдатлары күп кеңә көнне җылы ашсыз, икмәксез, коры сохари һәм кечкенә генә берәр кисәк дуңгыз мае белән кала*

башладылар. Г. Гали. [*Якуп*], *куй мае салдырып, йодрык зурлыгында гына вак күмәчләр пешертеп ала.* М. Гафури.

3. Үсемлек орлыкларыннан сыгып алына һәм суда эреми торган куе сыекча (бер төрләре ашамлык әйбере, икенче бер төрләре майлау материалы һ. б. өчен кулланыла). *Киндер мае. Чикләвек мае. Мамык мае. Зәйтүн мае. Агач мае.* □ *Фәриха, суганлап, борычлап, көнбагыш мае белән бәрәңге котлетлары куыра.* Ш. Камал.

4. Чыгышлары белән күбесенчә минералларга бәйле матдәләрдән алына торган сыек, ярым сыек яки куе матдә (ягулык яки техник майлау материаллары буларак һ. б. өчен кулланыла). *Машина мае. Шәм мае. Мылтык мае.* □ *Богатырев, үлчәүле савыт белән килеп, картерга май салды.* Ф. Хөсни. *Алар, бигрәк тә Галия апа, трактор маена шулкадәр буялганнар, тик тешләре белән күзләре генә елтырый иде.* Э. Касыймов. || *сөйл.* Керосин. *Мин язам, шунда күрәм: лампам эчендә май кими.* Г. Тукай. *Җиделе лампа якты яна, эчендә мае булса.* Җыр. || *күч. сөйл.* Бензин. *Машина „Казан" гостиницасы каршына килеп туктады. Мортазин, кинәт тирә-ягына карануп, [шоферга:] — Арбаңның мае бармы? Заводны күрәсе иде бит, — диде.* Г. Әпсәләмов.

5. Тирегә сылап сендерү, тәндәге ярага сөртү өчен дарулы һәм майлы матдәләрдән торган куе катнашма; *русчасы:* мазь. *Хатын [Илсөярнең] аркасындагы камчы эзенә ниндидер май сөртте дә яулыгын телгәләп бәйләп куйды.* Г. Гобәй.

6. *күч.* Яхшы, туклыклы, тәмле азык турында. *Күршеләр бай булды, Ашлары май булды.* Г. Тукай. *Баем, баем, бай гына, Инде кесә сай гына, Ашый алмый май гына, Җиккәне дә тай гына.* Г. Камал.

7. *күч.* Көч, куәт, егәрлек. [*Байлар*], *елан кебек, маең барда Сине тәмам имәләр икән. Маең бетеп, коры сөяк калгач, Сине читкә тибәләр икән.* М. Гафури. [*Зөбәйдә*], *техниканы авызлыклап, аның актык тамчысына кадәр маен сыгып ала. Шуңа күрә эшләп чыгару нормасын ике йөз дә биш процентка менгезде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

Май атлау — каймакны туглап, маен аерып алу. — *Рәүфә, эткәң белән миңа кечкенә самоварны --- шаулатып җибәр дә дүрт көнлек каймактан май атларга тотын.* А. Шамов. **Май ашы** — бодай онын йомыркага изеп, майда пешерелгән ашамлык; бавырсак. — *Иртән китсәң дә ярамыймы соң, улым? --- Юлга азрак май ашы да пешерер идем.* Р. Ишморат. **Май бизләре** *анат.* — кешеләрдә, имезүче хайваннарда май сыман матдәләр бүлеп чыгара торган тире бизләре. **Май канаты** — таба ашларын майлау өчен каз яки үрдәк каурыйларыннан торган бәйләм. *Илсөяр, бер кулына май канаты, икенче кулына күкәй бутагыч тоткан килеш, ишектән башын сузып Шәмсигә ымлады.* Г. Мөхәммәтшин. **Май төшү** — туглау нәтиҗәсендә каймакның майга һәм әйрәнгә аерылуы. *Су язып май төшми.* Мәкаль. **Май әби** *этн. диал.* — әбисенең яки бабасының әнисе. [*Тансык*] *авыл буйлап кешеләрнең җилкә өстендә колашалы кабыкта баручы май әбисенә, колга башы тоткан кешеләргә моңаеп карый.* Г. Ахунов. **Май җитене** — майлы культура буларак игелә торган, орлык уңышын мул бирә торган җитен төре.

◇ **Мае чыгу** — нинди дә булса эштән, сөйләшүдән һ. б. файда, нәтиҗә булу турында. *Сөйләсәң, сүзнең мае чыга, үзем барып сөйләшим әле, — диде Гарәфи абзый.* Г. Әпсәләмов. *Чүбек чәйнәп май чыкмады, чыкмаячак.* Г. Камал. **Маен чыгару** — 1) тиешенчә файдалану, мөмкин булганның барысын да алу; 2) тәмам жиренә житкереп, бик җентекләп эшләү. **Маена чыдый (чыдаша, түзә) алмау, маена сыймау (сыешмау)** — рәхәтлектән, мул тормыштан бозылу, узыну. — *Байлар да әчәләр, алар майларына чыдый алмый әчәләр.* Х. Садрый. [*Саттар Әминәгә:*] *Маеңа сыймый башладыңмыни!* Ф. Сәйфи-Казанлы. — *Тыныша алмадым... Зоотехник белән. Тылда утырып, маена чыдаша алмый башлаган бюрократ шунда.* А. Расих. **Май ашаган** — суйган мал бик симез булганда әйтелә. **Май ашаган (урлаган) мәче кебек (төсле)** — ниндидер шуклык, мутлык яисә гаеп эш эшләргә җыенучы яки эшләгән кешенең үз-үзен тотышы турында. — *Син, нәкъ әнә шул май ашаган мәче төсле, ничнәрсә белмәгән булып кыланып утырасың.* Ш. Камал. *Безнең күршедә генә берсе май урлаган мәче кебек әмма күзләрен елтыратып йөри дә соң.* Ф. Хөсни. **Май басу** — артык симерү, май катламы белән каплану. *Май баскан мине. Колхозда да шулай дип йөртәләр. „Май баскан Баһау" диләр.* Г. Минский. **Май кап** — үзең генә бел, башкаларга сөйләмә, мыштым тор (кисәтеп, сер итеп әйтү). — *Син бел дә мин бел инде, Бибифатыйма абыстай, май кап, — диде Гайнулла абзый.* А. Расих. **Май кебек (төсле, шикелле)** — 1) өйнең, киемнең, көннең, суның һ. б. ш. бик җылы булуы, тәнгә рәхәт булуы турында. *Ягып җибәргәч, вагон эче май төсле җылынып китте.* Ш. Усманов. — *Бар, син дә коен, су май кебек.* Г. Әпсәләмов; 2) эшнең әйбәт, уңышлы баруы турында. — *Хәзергә һәммәсе дә май кебек.* Ф. Бурнаш; 3) бик ягымлы, мөлаем; 4) бик күндәм, тыңлаучан, тәртипле. *Балалар аның янында май кебек булып кайталар.* А. Шамов; 5) сөйләшү, сүз һ. б. ш. турында: бик ягымлы, күнелгә хуш килә торган. *Тавышы матур, үзе батыр. Май шикелле сүзләре.* Ә. Ерикәй. **Май кебек эрү** — 1) рәхәтләнү, ләззәтләнү, бик канәгать булу. *Галимәнең хатлары ярату һәм иркәләү белән тулы була иде. Бичара Гөлсем апа аларны укыганда май кебек эреп китә торган иде.* Г. Әпсәләмов; 2) рәхәтләнеп, изрәп йоклап китү турында. *Нинди хикмәтедер, әби түшәгән шул урын мине май кебек эретә дә җибәрә торган иде.* Г. Гали. **Май тибү** — *к.* маена чыдый алмау. — [*Заһидулла мулла никахлы өч хатыны өстенә ике сөяркә тоткан.*] *--- Шуңа ни әйтәсең инде? Төшем күп, эш юк. Май тибә, нишлисең?* Ш. Камал. **Май төшерү** — ябыгу, тәндәге артык майны киметү, бетерү. [*Куроттна*], *физкультура залындагы көбек, кешеләрне үрмәләтеп, майларын төшерәләр икән.* Г. Әпсәләмов. **Май шикелле ягылу** — бик ягымлы булып кылану, ялагайлану. *Нәгыйм минем белән бер сүз, ике сүз гәпләшеп китте. Бик йомшак сөйли үзе, Май шикелле ягыла.* Ш. Камал. **Май җыю** — симерү. **Майга китү** — симертү. *Май майга китә, шулпа гына кая китә.* Мәкаль. **Майга ут төртү** — нинди дә булса эшкә котырту, кыздыру. — *Без [бу бандитлар шайкасын] хәзерге хәлендә дә бик әйбәт файдалана алабыз. Тик майга утны төртә белү генә кирәк.* Ә. Айдар. **Майда йөзү (йөздерү)** — байлыкта, муллыкта рәхәт, ваемсыз яшәү (яшәтү). — *Дөресен сөйләгән кешегә монда тынгы юк. Ялагайлансаң, ярарга тырышсаң, майда йөзәсең.* Н. Фәттах. — *Яхшылыкның кадерен белә торган бәндә булсаң, гомерең буена майда йөздерәм бит мин сине!* Г. Бәширов. **Майдай итү** — җайлау, көйләү; нәрсәгә дә булса бик жиңел ризалату, күндерү. — *Егет ягы шулай булып чыкса, Зифасын минем хәйләм дә майдай итәр.* М. Фәйзи. **Майсыз табада куыру (сикертү)** — кемне дә булса үз теләгенне, кушканыңны каршылыксыз үтәп торырга мәҗбүр итү. [*Илтабан Карачәчкә:*] *Менә син атаңны майсыз табада борчак урынына сикертәсең бит әле.* Н. Исәнбәт.

МАЙ I *и.* 1. Календарь елның бишенче ае. *Тормыш таңы бит ул — май көннәре, Анда кемнәр генә җырламас.* М. Гафури. *Майның яме күке белән.* Мәкаль.

2. *күч.* Матур, яхшы; рәхәт (май аендагы кебек җылы, матур, ямьле, рәхәт). *Көннәрең дә, төннәрең дә Яктылыкка бай синең; Җәйләрең дә, көзләрең дә, Кышларың да май синең!* З. Мансур.

Май бәйрәме — *к.* **Беренче май бәйрәме.** *Май бәйрәме гөлләр белән килә, Тирә-ягым минем ямь бүген.* Ә. Ерикәй. **Май коңгызы** — җәенке мыеклылар семьялыгыннан җиләк-җимеш агачларына, урманга һ. б. корткычлык итә торган кызгылт көрән төстәге коңгыз (май аенда оча башлый). *Һавада нечкә һәм якты әзләр калдырып, утлы бөҗәкләр очты. Май коңгызы пырылдады.* Г. Әпсәләмов.

МАЙКА *и.* Җиңсез, якасыз трикотаж эчке күлмәк. *Җәй көне бияләй, кыш көне майка сатып ал.* Әйтем.

МАЙЛАВЫЧ *и.* Арба майлау өчен кылдан эшләнгән пумала.

МАЙЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* майлау. *Җиңги өстәлгә --- майланган коймак китереп куйды.* Ә. Айдар.

2. Май таплары эзләре калу, майга буялу. *Майланып беткән юка пиджак аркылы салкын җил куенга кереп йөрәккә үтә.* Х. Садрый.

3. *күч.* Майлаган шикелле ялтырап күренү турында. *Аның йөзе һәрвакыттагыча майланып ялтырап тора.* Ф. Әмирхан.

МАЙЛАП *рәв.* Май белән (ашау, эчү турында). *Чәй эчерербез үзеңә, Баллап, майлап, конфетлап.* М. Гафури.

МАЙЛАП-ҖАЙЛАП *рәв.* 1. Оста итеп хәйләләп, юмалап. *Күз алдыннан уза кәләпүшчеләр, Майлап-җайлап алдаучы кәвешчеләр.* Н. Баян.

2. Күндерерлек, ышандырырлык итеп. — [*Мине шәһәрдән*] *җибәрмәсләр шул, Вәли абый. — Җибәрерләр, шундый майлап-җайлап, колхоз печатен басып, кәгазь язып салырбыз заводыңа.* С. Рафиков.

МАЙЛАУ *ф.* 1. Ашны тәмләтү, камыр табага ябышмасын һ. б. өчен май (1—3 мәгъ.) салу, ягу. [*Солдат*], *хатынына карабодай я ясмык коймагы пешертеп, шуны каз мае белән майлап, яңа сауган сөт белән чәй эчәр иде.* М. Гали. — *Әбине ачуландырдың, — диде Мохтар* [*Фәйзигә*]. — *Менә инде ул шуның өчен иртәгә безне майламаган тары боткасы белән сыйлар.* Ш. Камал. || Авырткан урынны дәвалау өчен май (5 мәгъ.) сөртү, сылау. *Әгәр ул* [*Шәмгун*] *доктор булса, даруын-мазарын бирер, кирәк урынын майларга, тиешлесен эчәргә кушар иде.* А. Шамов. || Матурлау, ялтырату, шомарту өчен махсус май сөртү. *Кара бөдрә чәчләремне Майлыймын да тараймын.* Җыр. || Төрле механизмнар шома, җиңел хәрәкәт итсен, әйләнсен, тутыкмасын һ. б. өчен май (4 мәгъ.) салу, сылау. *Мылтыкны майлау. Тегү машинасын майлау.* □ *Төнлә белән арба тәгәрмәчләрен дегет белән бик әйбәтләп майлап куйганнар.* Г. Галиев. *Алар өчәүләп үзләренә яраклы чаңгылар сайлап алдылар, әйбәтләп майладылар.* Г. Ахунов. || *с. мәгъ.* Шундый максат өчен билгеләнгән. *Майлау әйберләре.*

2. *күч.* Берәр максат белән ришвәт бирү, сыйлау. *Майламыйча җайланмый.* Мәкаль. *Инде иблис барча эшне җайлады: Оста тел берлән халыкны майлады.* Ш. Бабич.

3. *күч. жарг.* Аракы эчү турында. *Константин Михайловичның тамагы карлыккан иде. Шуңа күрә тагын майлап чыгарга булды.* Соц. Тат.

◇ **Майлаган кебек (шикелле)** — бик яхшы, җай белән, ягымлы. — [*Әткәй*] *атналар буе шулай, майлаган кебек, ал да гөл, син дә мин булып йөри.* Г. Ибраһимов. **Майлаган кебек (шикелле)** яки **майлагандай бару (тәгәрәү)** — яхшы, җиңел, тоткарлыксыз эшләнү турында. — *График белән булгач, барысы да майлагандай барыр, бер җирдә дә сөртенмәбез кебек иде.* Ф. Хөсни. — *Амбар тулы ашлык, абзар тулы мал-туар дигәндәй, эшләр майлаган шикелле тәгәрәп кенә бара.* Г. Бәширов. **Майлагандай (майлап куйган кебек) булу** — әдәпләнү, тәртипләнү. — *Ярый, мин* [*шәкертләрне*] *бүген үк күреп колакларын борырмын. Аннан майлагандай булырлар.* Т. Гыйззәт. — *Курыкма, ахирәт...* [*Шакирә*], *кияүгә чыкса, майлап куйган кебек булыр, күрерсең.* Ш. Бикчурин. **Майлап ташласаң, эт ашамас** — эшәке, начар, гадәтсез (кешегә карата). [*Бәдри Гыймадига:*] *Тфу, шүрәле, майлап ташласаң, эт ашамас, ыштыр бит, сиңа калган өйләнергә.* К. Әмири.

МАЙЛАУЧЫ *и.* Машиналар майлаучы. *Пароходта шапшак кына киенеп йөргән матросларны, кочегарларны, майлаучыларны хәзер танырлык та түгел иде.* С. Сабиров.

МАЙЛАЧ *с. диал.* Ялтырап торган, симез. *Торып аягына баскач,* [*Бардинаның*] *пөхтә генә хәрби киеме якасында медицина еланы белән бер шпалы барлыгы һәм майлач кына йөзле булуы күренде.* Ш. Маннур.

МАЙЛЫ *с.* 1. Майланган, майда пешерелгән, эченә май салынган; май ягылган. *Майлы күмәч. Майлы бәрәңге.* □ *Һаман-һаман майлы ботка булмый.* Мәкаль. || Мае (2 мәгъ.) күп булган, симез (ит турында). *Майлы казылык.* □ *Сарсымбай, акрын, сабыр сайлап, кулына биш турам майлы ит алды.* Г. Ибраһимов.

2. Үзендә мае булган, май алу өчен файдаланыла торган. *Майлы культуралар. Майлы матдәләр.* || Майда изеп ясалган (буяу турында). *Стенага майлы буяу белән эшләнгән көчерәк бер картина эленгән.* А. Шамов.

3. Май буялган, май таплары тигән; май сеңгән. [*Егетләр*], *читләре ашалып беткән майлы карталарны югары чөеп, серле сүзләр кычкыралар иде.* К. Нәҗми.

4. *күч.* Дәртле, азгын хисләр чагылдыра торган (күзләр, караш, елмаю турында). [*Әпипәнең*] *майлы күзләре мутланып ялтыйлар.* Г. Бәширов. | *рәв. мәгъ. Сестра* [*палатадан*] *чыгып китәкч, Хасият, майлы гына елмаеп, телен шартлатып куйды.* А. Шамов. || Хәйләкәр, комсыз. *Ала күздә акыл булмый, Майлы күздә ягым булмый.* Мәкаль. *Майлы күзле майор бу сыйдан Кәефләнде, тәмам исерде.* М. Җәлил.

Майлы аш — составында ит, май кебек нәрсәләр булган затлы, җимле, туклыклы азык турында. [*Ул*] *туйда төрле майлы ашлар, гөбәдияләр, бәлешләр ашаган.* Н. Исәнбәт. **Майлы гөмбә** *бот.* — эшләпәсе май сыман лайлалы юка элпә белән капланган гөмбә; *русчасы:* маслёнок. *Үзе яшь, үзе нарат урманы да булганга, үзе урман авызы да булганга,* [*биредә*] *бер дигән майлы гөмбәләр дә бар иде.* Г. Хәсәнов.

◇ **Майлы ботка (ашау) түгел** — җиңел түгел, авыр, кыен. *Солдат тормышы майлы ботка түгел инде ул.* Ш. Маннур. *Аксар бригадасына җитәкчелек итү майлы ботка ашау түгел.* С. Рафиков. **Майлы калҗа** — бик файдалы, төшемле эш һ. б. турында. *Тирә-як авыллардан казнага тире-яры, сүс, йомырка җыю --- әлегә кадәр Идият кулында иде. --- Хәзер бу майлы калҗаны Малик үз кулына алмакчы була.* И. Гази. **Майлы кукиш** *гади с.* — бернәрсә

дә бирмәү, сорауны тупас һәм кискен рәвештә кире кагуны белдерә. [*Батыржан:*] *Миллэт харап булмасын дисәгез - - - акча бирегез.* [*Мисбах:*] *Менә моңысы сәүдәгәр кукишы, ә менә моңысы майлы кукиш.* К. Тинчурин. **Майлы таба ярату** — җиңел юл белән табылган муллыкка кызыгу. *Шәмгун ул майлы табаны ярата. Шундый киң холыклы кеше инде.* А. Шамов. **Майлы урын** — файдалы, табышлы урын.

МАЙЛЫЛЫК *и.* Берәр нәрсәдә майның күпме булу дәрәҗәсе. *Майлылык процентын билгеләү.* □ *Хатта, - - - Рәхим биргән киңәшләрне тоту аркасында, совхоз сөтнең майлылыгын, сыйфатын арттырганлыгы турында язылган иде.* А. Расих.

МАЙМАК *с. иск.* Йомшак һәм янякка аеры. *Төя аягы маймак, түрә аягы тайгак.* Мәкаль.

МАЙМЫЛ *и.* 1. Тән төзелеше буенча кешегә иң якын торган имезүче хайван. *Мин диңгезләр уртасындагы маймыллар, алтын койрыклы тавислар яши торган яшел утрауларга барып чыгам.* Г. Бәширов. *— Нигә миңа ул маймыл, минем маймыл биетеп йөрер вакытым узган.* Ә. Фәйзи.

2. *күч. сөйл.* Башкаларга иярүче, башкаларны үртәүче, кыланчыкланучы кеше турында.

3. *күч. сөйл.* Бик ямьсез, кыяфәтсез кеше турында. *Былтыр маймыл Хафизга җен-пәри ияләште.* Г. Тукай.

Маймыл агачы — *к.* баобаб.

МАЙМЫЛ-КЕШЕ *и.* Кешелек дөньясының беренче вәкиле; *к.* питекантроп. *Борынгы маймыл-кешеләрнең сөякләрен галимнәр башта Ява атавында тапканнар.* А. Тимергалин.

МАЙМЫЛЛАНУ *ф.* Кыланчыклану; кемгә дә булса охшарга тырышып кылану. [*Борис*], *үз-үзеңә тромбон уйнап, „Волга-Волга“ кинокомедиясеннән - - - такмаклар әйтеп маймыллана, озын, чандыр гәүдәсен бөгә-сыга көйли.* М. Хәсәнов. *— Миңа икейөзләнергә кушасыз? Алдашырга, маймылланырга?* Н. Исәнбәт.

МАЙМЫЧ *и.* 1. Уылдыктан яңа гына яралган вак балык. [*Һәрбер сазан балыгы*] *уртача алганда 200 мең уылдык чәчә, шулардан ким дигәндә 60—70 мең маймыч ярала.* М. Шабай. [*Хәким*] *мәктәптә дә, өйдә дә, пыяла савытларга су салып, маймычлар үстереп мәш килә торган иде.* С. Сабиров.

2. *күч. сөйл.* Кечкенә (бала турында). *Көрәш башланды. Иң әүвәл нәниләр тотынды. - - - Ни күрим, үзе кебек бер маймыч белән безнең Дамир да изалана.* Э. Касыймов.

МАЙНА *ы.* Порт йөкчеләре, моряклар, төзүчеләр, кранчылар телендә „түбәнгә!“, „түбән төшер!“ мәгънәсен белдерә торган команда; *киресе:* вира. *Кранчыга, баш бармакны аска күрсәтеп, „майна!“ кычкырырга туры килә.* Ш. Маннур.

МАЙОЛИКА *и.* 1. Яндырылган һәм ялтыравык (глазурь) тышча, рәсемнәр белән каплатылган сутлы балчык; шуннан ясалган эшләнмәләр. [*Павильонның*] *ян як ишекләренә дә матур төстәге майолика белән милли орнаментлар ясалган.* Каз. утл.

2. Шундый эшләнмәләр ясау сәнгате. *Майолика белән шөгыльләнү. Майолика остасы.*

МАЙОНЕЗ *и.* Үсемлек мае, йомырка сарысы, серкә һ. б. ш. аш тәмләткечләр катнашмасыннан торган куе соус.

МАЙОР *и.* Капитан белән подполковник арасындагы хәрби дәрәҗә; шул дәрәҗәдәге офицер. *Капитан Газизов майор Закиров белән янәшә утыра иде.* А. Шамов.

МАЙОРАН *и. бот.* Кызыл һәм ак чәчәк ата торган хуш исле куак үсемлек (медицинада, парфюмериядә һәм кулинариядә кулланыла).

МАЙОРАТ *и. кит.* Революциягә кадәрге Россиядә һәм капиталистик илләрдә мирас системасы (бу система буенча мирас булып калган җир һәм милек ир балаларның олысына яки нәселдәге олы кешегә күчә); шул рәвешле мирас булып тигән җир яки милек.

МАЙСЫЛ *с.* Май сеңгән, май сыман матдә белән капланган. *Чәчелеп китте вак-вак кына майсыл Яфраклардай сары кәгазьләр.* Х. Камалов.

МАЙТАРУ *ф. сөйл.* Эшләү, башкару, булдыру. *Егет, чынлап та, берәр эш майтарырга җыена иде булса кирәк.* Ф. Хөсни. *Олы малай бераз ярдәм итәргә булган иде. Аның акчасына гына әллә ни майтарып булмастыр, ахры.* Каз. утл.

МАЙЧЫ *и.* Май сату белән кәсеп итүче. *Залда инә төшәрлек тә урын калмады. - - - Урта сафларда вак сәүдәгәрләр, кибетчеләр, тиречеләр, майчылар.* Г. Минский.

МА'ЙЯ *и.* Юка киҗе-мамык тукыма.

МАЙҮЛЧӘГЕЧ *и. махс.* Сөтнең майлылык дәрәҗәсен билгели торган прибор.

МАКА'КА *и. зоол.* Тар борынлылар семьялыгыннан кулга җиңел ияләшә торган кечкенә маймыл (Африкада, Һинд-Кытайда яши).

МАКАРОН *и.* Төче камырдан нечкә көпшә рәвешендә киптереп хәзерләнгән токмач. *Ашка макарон салу. Кыздырылган макарон.*

МАКАРОНИЗМ *и. кит.* Сөйләмгә чит телдән үзгәртелмичә кертелгән сүзләр яки әйтелмәләр.

МАКАРО'НИК *с. кит.* Макаронизмнар белән чуарланган. *Макароник стиль.*

МАКАРОНЛЫ *с.* Макароннан хәзерләнгән, макарон салып пешерелгән. *Якшәмбе көнне безгә - - - макаронлы аш бирдәләр.* Каз. утл.

МАКЕДО'НИЯЛЕ *и.* Югославия Македониясендә, Болгариянең кайбер районнарында һәм грек Македониясендә яшәүче төп халык вәкиле — Көньяк славян халкының бер кешесе.

МАКЕТ *и.* Нәрсәнең дә булса кечерәйтеп ясалган күренеше; модель, үрнәк. *Самолёт макеты. Электростанция макеты.* □ *Мәрьям һәйкәлнең макетын ясады.* М. Маликова. || *махс.* Басылып чыгарга тиешле әйбернең (китапның, газетаның, журналның һ. б.) сынау, тикшереп карау өчен төзелгән экземпляры. *Газетаның җаваплы секретаре Гали Хужи [чираттагы санның] макетын төзи.* Г. Бакиров.

МАКЕТЧЫ *и.* Макет ясаучы. *Макетчылар бригадасы җитәкчесе Давид Лехтман һәм макетчы Михаил Поляков судно күтәргеч макетының эшен тикшерәләр.* Соц. Тат.

МАКИНТОШ *и.* Су үткәрми торган тыгыз тукымадан тегелгән җиңел пальто. *Ишектә - - - өстенә әйбәт макинтош кигән, эшләпәсен кулына тоткан Антонов күренде.* Г. Әпсәләмов.

МАКИНТОШЛЫ *с.* Макинтош кигән. *Макинтошлы, чандыр битле, урта яшьләрдәге кеше нефтьчеләр профсоюзы Үзәк Комитетыннан Харабаров булып чыкты.* Г. Ахунов.

МА'КЛЕР *и.* Буржуаз җәмгыятьтә сәүдә һәм биржа килешүләре төзүдә сатучы белән алучы арасында эш йөртүче профессиональ арадашчы. *Мин шул бер сөйләшә башласам, Казан маклерлары шикелле, авызны яба алмыйм.* Г. Тукай. *— Син нәрсә! Башкинның маклеры булдыңмыни? Маклер булсаң, ат базарына бар!* Г. Минский.

МАКЛЕРЛЫК *и.* Маклер эше, кәсебе. *Маклерлык белән шөгыльләнү.*

МАКМАЛ *и. иск.* Бәрхет. | *с. мәгъ. Яхшы атаның баласы — макмал тунның якасы.* Мәкаль.

МАКМЫР *и. сөйл.* Күп эчүдән соң иртәгесен була торган хәлсезлек, бик каты баш авырту, үзеңне бик начар хис итү хәле; аракы чире. *Кичәге макмыр аның башын кургаш тутырган кебек авырайтып, томалап торды.* Ә. Фәйзи. *Аракы макмыры бетә, байлык макмыры бетми.* Мәкаль.

МАКМЫРЛАУ *ф. сөйл.* 1. Күп эчүдән соң иртәгесен авырып йөрү, баш авырту белән җәфалану. || *күч.* Исерткеч эчемлек эчеп, макмырны бетерү (баш авыртуын басу).

2. *диал.* Күп ашаудан авыру; үтләү.

МАКМЫРЛЫ *с.* Макмыр хәлендәге; исәңгерәгән, бик нык авырткан. *Макмырлы баш белән йөрү.*

МАКРЕЛЬ *и. зоол. к.* скумбрия.

МАКРО- Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) зур, эре, мәсәлән: **макродөнья, макрорайон;** 2) эре предметларны, зурлыкларны тикшерү белән бәйләнгән, мәсәлән: **макробиотика, макроскопия.**

МАКРОКЛИ|МАТ *и. махс.* Җир йөзенең бик зур мәйданына мөнәсәбәтле климат; *киресе:* микроклимат.

МАКРОКОСМ *и. кит.* Дөнья, галәм; *киресе:* микрокосм.

МАКРОСКО|ПИК *с. махс.* Гади күз белән күреп була торган; *киресе:* микроскопик. *Макроскопик процесслар.* || Гади күз күреме белән башкарыла торган. *Макроскопик күзәтүләр.*

МАКРОСТРУКТУ|РА *и. махс.* Каты әйберләрнең гади күзгә күренеп торган яки лупа аша күреп булган төзелеше; *киресе:* микроструктура. *Туфракның макроструктурасы.*

МАКСАТ *и.* Алга куелган бурыч; ирешергә, булдырырга омтылган нәрсә. *Бу бөек кешеләрнең төп максатлары үз бәхетләрен кайгыртудан күп югары булган.* Г. Кутуй. *Максат ачык билгеле булса, аңа ирешү юлларын табу җиңел.* М. Әмир. || Алдан билгеләнгән берәр төрле ният. *Газинур --- Сәлимнең моны ниндидер яшерен максат белән эшләвен башына китерми иде.* Г. Әпсәләмов. — *Максатыма инде тәмам җитәм. Шатлана-шатлана* [*Әхмәттән*] *үчемне алам.* Г. Камал.

Максат хәле *лингв.* — җөмләдә процессның үтәлүүтәлмәү, билгенең булу-булмау максатын белдерә торган иярчен кисәк. **Максат җөмлә** *лингв.* — баш җөмләдәге эш яки хәлнең максатын белдерә торган иярчен җөмлә.

МАКСАТЛЫ *с.* Билгеле бер максатка хезмәт итә торган, нинди дә булса максатка юнәлтелгән. *Максатлы эш.* □ *Минем юлым авыр, ләкин максатлы юл.* Г. Коләхметов.

МАКСА|ТЧА *рәв.* Максатка ирешерлек юнәлештә, максатка яраклы рәвештә. *Максатча эш итү.*

МАКСАТЧАЛЫК *и.* Максатка ярашлылык, максатка туры килүчәнлек. *Үсемлек һәм хайваннар систематикасында класслар, отрядлар, ыруглар һәм төрләрне аеруны билгеләп, К. Линней бу категорияләрне куллануның максатчалыгын башка фәннәрдән мисаллар китереп аңлаткан.* Биология.

МАКСАТЧАНЛЫК *и.* Билгеле бер максатка омтылыш; фикер, эшчәнлекнең билгеле бер максатка буйсындырылган булуы. [*Хафиз Гайнуллинның*] *ихтыяр ныклыгы һәм максатчанлыгы тагын да көчәйгән.* Г. Әпсәләмов.

МАКСИМ *и. сөйл.* Станоклы пулеметның бер төре.

МАКСИМАЛИЗМ *и. полит.* 1. Нинди дә булса карашларны, таләпләрне реаль чынбарлык белән аклanмый торган чиккә җиткерү.

2. Эсерлардан аерылып чыккан үтә сул, ярым анархистик-террористик агым.

МАКСИМАЛИСТ *и. полит.* 1. Максимализм (1 мәгъ.) тарафдары. *Газетабызда большевиклар катнашкан кебек, зур эсерлар һәм максималистлар да катнаштылар.* Г. Ибраһимов.

2. Ярым анархистик-террористик эсерлар группасы члены.

МАКСИМАЛЬ *с.* Иң югары, иң зур (башкалар рәтендә); соңгы чиккә җиткерелгән. *Максималь басым. Максималь керем.* || *рәв. мәгъ.* Киң күләмдә, тулысынча, мөмкин кадәр күбрәк. *Минераль ашламалардан максималь файдалану. Халыкның материаль һәм культура ихтыяҗларын максималь канәгатьләндерү.*

МА|КСИМУМ *и.* 1. Иң зур микъдар; *киресе:* минимум.

2. *рәв. мәгъ.* Иң күбе(се); иң зуры(сы); күп дигәндә.

МАКСУН *и. зоол.* Себер елгаларында яши торган, гәүдә төзелеше белән ала балыкка охшашлы балык.

МАКСУТ, МАКСУД *и. иск. кит.* — *к.* максат. [*Егет*] *бу ишарәте белән үзенең максутын аңлатмакчы була иде.* М. Гафури. — *Әхмәт әфәнде, --- минем монда сезне алып килүдән максудым шул иде: бай минем хакта сезгә ниләр сөйли?* Г. Камал.

МАКСЫМ, МАКСЫМА *и. диал.* Колмаксыз эчетелгән бал. *Андрюша Лексей --- алдына тар авызлы чүлмәк белән максыма китереп куйды.* К. Латыйпов.

МАКТАЛУ *ф.* Мактауга лаек булу, мактап телгә алыну. *Кыз мактала эш белән, Түгел энҗе теш белән.* Г. Камал. *Илдар инде уңган егет, Совхозда да мактала.* М. Җәлил.

МАКТАНУ *ф.* 1. Үз-үзеңне яки берәр эшеңне мактау, мактап сөйләү. *Мин-мин дип мактану, эшең хак булса, урынына күрә ярый.* К. Насыйри. — *Үземнең, әткәй белән әнкәйнең, әбинең исемнәрен яза беләм,— диде Габделкаюм, мактана төшеп.* М. Гали. *Бикмулла үзенең күрәзәлеге белән мактанмыйча булдыра алмады.* Ә. Еники.

2. Горурлану, горурлык хисе кичерү. *Акбитнекеләрдән һәр гаиләнең шәҗәрәсе Моратайдан башланып китә, аның токымы батыр бабасы белән әле дә мактана.* Г. Бәширов. *Мактан, Казан! Данлы яшьлек чагы Сиңдә үтте бөек Ленинның.* Ә. Исхак.

3. Урынсызга үз-үзеңне яки берәр эшеңне мактау, булмаганны арттырып сөйләү; шапырыну, масаю. *Вәли бай һәр җирдә миң болай, мин тегеләй эшләдем, дип мактанып йөри.* Г. Нигъмәти. *Юньсез мактаныр, юньле сакланыр.* Мәкаль. *Мактану һәркемне хур итә, тыйнак булуга ни җитә.* А. Алиш. || Берәр эшнең уңай хәл ителәчәге турында алдан шапырынып сөйләү. *Буаз дигәч, мин инде аның булачак колының, әлбәттә, алмачуар дип башыма да утырткан, бөтен ипташләремә мактанып беткән идем.* Г. Ибраһимов. — *Галләмнең эш өзелеп бетмәс борын ук мактанып йөрүенә кем гаепле?* М. Фәйзи.

◇ **Мактанудан түгел (булмасын), мактанып әйтүем түгел** *кер. сүз.* — мактану, шапырыну, арттырып сөйләү булмауны алдан кисәтеп әйтелә. *Мактанудан түгел, Гарәфи бит Уралын да, Себерен дә, Кырымын да күргән кеше.* Г. Әпсәләмов. — *Мактанып әйтүем түгел, кулымда корал булганда, куркаклыкны белми идем мин.* А. Шамов.

МАКТАНЧЫК *с.* Мактанырга, шапырынырга, масаерга яратучы. *Хәйри үзе, ул чакта, яшьләр арасында булмаса да, аңа мактанчык бай бәтчәнең сүзләрен бик тиз җиткергәннәр.* Г. Минский. *Мактанчык кешенең бар акылы мактануга китәр.* Мәкаль. | *и. мәгъ. Әй, фашист, мактанма син, — күпне күргән дөнья бу! Күпме мактанчыкны хурлыкка төшергән дөнья*

бу! Ә. Исхак. || Мактану билгеләре сизелеп торган. *Мактанчык кыланышлар. Мактанчык тон белән сөйләү.*

МАКТАНЧЫКЛЫК *и.* Мактанчык кешегә хас сыйфат. [*Әмиржанның*] *мактанчыклыгы һәм бөтен кешедән күп беләмлек дәгъвасында булуы Хөснуллага һич тә ошамый иде.* Ш. Камал.

МАКТАНЫЧ *и.* Мактауга лаеклы кем яки нәрсә; горурлык.— *Син — заводыбызның мактанычы бит. Син — шундый гүзәл проектның авторы.* Г. Иделле. *Казан шәһәренең зур мактанычы бит бу йорт* [*университет*]. М. Әмир.

МАКТАНЫЧЛЫ *с. сир. к.* мактаулы. [*Ахырда кунакларга*] *Фәтхия карчыкның - - - мактанычлы җимеш суы бирелде.* Г. Ибраһимов.

МАКТАУ *ф.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса яхшы, күркәм, уңай, файдалы ягын хуплау, яхшы дип сөйләү; *киресе:* яманлау. *Мактап телгә алу. Мактап язу.* □ *Сандугач чынлап та Хәят өчен сайрый, аның матурлыгын мактый - - - шикелле иде.* Ф. Әмирхан. || Яхшы дип санау, табу; хуп күрү. *Изге эшне китап мактый.* Әйтем. || Данлыклау, нәрсәгә дә булса дан җырлау. *М. Гафуриның революциядән соңгы иҗатында киң урын алган темаларыннан берсе — хезмәтне мактау.* М. Җәлил. *Москва, сине мактап җырлый халык Кайнар, дәртле матур җырында.* Ә. Ерикәй.

Мактау кәгазе (грамотасы) — кемгә дә булса бирәр төрле эштә, спортта һ. б. ирешкән уңышлыкларын зурлап, хөрмәт итеп бирелә торган рәсми язма таныклык. *Инде ул биш мәртәбә бүләкләнгән. Мактау кәгазьләре алган.* Ф. Кәрим. **Мактау тактасы** — яхшы эш күрсәткечләренә ирешкән кешеләрнең фоторәсемнәре һәм исемнәре язып куелган такта (витрина).

◇ **Мактап бетерә алмау** — артык, чиктән тыш мактау. *Миңсылу бигрәк тә Дускаевның хатынын мактап бетерә алмый иде.* Ә. Еники. **Мактап йөрисең икән** — ашап-эчеп утырганда чит кешенең килеп керүен яхшыга юрап әйтелә.— *Һай рәхмәт төшкерләре, мактап йөрисез икән, түрдән узыгыз, әллә ни сый-хөрмәт юк-югын.* М. Шабай.

МАКТАУЛЫ *с.* 1. Мактауны, хуплауны эченә алган. *Мактаулы сүзләр сөйләү.* □ — *Яхшы ата баласы дигән мактаулы исемнән дә кадерлерәк нинди мирас кирәк сиңа!* Р. Ишморат.

2. Мактауга лаеклы; мактау, дан, хөрмәт китерә торган.— *Кечелектән олы булган кеше һәркем каршында да мактаулы.* Ф. Бурнаш. *Сәлим үзенең никадәрле мактаулы эш эшләгәнен хәзер генә аңлый башлады.* Г. Гобәй. || Нәрсә белән дә булса билгеле булган, танылган.— *Әптерәш бабай, син бит байга яраү белән мактаулы ялчы идең.* Г. Ибраһимов.

3. Күрсәткән хезмәтләре өчен ихтирамга, хөрмәткә лаек булган. [*Г. Тукайның*] *әдәби мирасы - - - социалистик илебезнең бәхетле хезмәт ияләре каршында югары һәм мактаулы урын тота.* Ш. Камал. [*Сәгъдәт апа*], *ударниклар сафына язылып, намуслы эш белән бу мактаулы исемне хәзерге көнгә кадәр нык рәвештә саклап килә.* Ф. Кәрим.

МАКУЛАТУ'РА *и. махс.* 1. Басу вакытында бозылган яки гомумән файдаланылганнан соң яңадан эшкәртүгә китә торган басма кәгазь. *Китапларның шактый өлешен макулатурага тапшырырга мәҗбүр булганнар.* Каз. утл.

2. *күч.* Бик түбән сыйфатлы әдәби әсәр турында.

МАЛ *и.* 1. *җый.* Дүрт аяклы йорт хайваннары; терлек. *Мал асрау. Малларны көтүгә чыгару.* □ *Мал — иясенә охшый.* Мәкаль. *Үләнле җирдә мал симерер. Мәкаль. Киң утарга чыкты колхоз малы, Сагынып җылы, иркен җәйләрне.* Ш. Маннур.

2. Байлык, милек. *Мин кызыкмыйм һич кешенең малы, милке, бәхтенә.* Г. Тукай. *Ялкауларның өлеше юк Безнең колхоз малында.* Җыр. || Табыш, керем, акча. *Үйлап йөри шунда безнең эшче: „Без эшләгән малны кем ала?“* М. Гафури. *Чит илләрдә йөреп малсыз кайтсаң, әтиең, әниең, сөйгәнең ят була.* Җыр. || Нинди дә булса кыйммәте булган яки файдаланырга яраклы әйбер турында.— *Я, әйт әле, әти, моны* [*герне*] *нигә дип күтәреп кайттың? — Нигә алып кайтмаска, мал лабаса ул.* Ш. Хөсәенов.

3. Сату итү әйберләре; товар. *Малны күрсәтеп саталар.* Мәкаль.— *Кибеттә мал бик аз калды. Күп нәрсәләрнең төрләре беткән.* Г. Камал. || *күч. гади с.* Кешегә җанлы товар итеп карап, кимсетеп әйткәндә кулланыла. [*Сирай, Ярулланың Мавиягә якынлашканын күреп:*] *Әй, син минем малга якын юлама! — Синең кебек аксакларга кул мал түгел ул.* М. Фәйзи.

Мал өе — кыш көне яшь терлекләрне (бозау, сарык бәрәннәре һ. б.) ябып тора торган өй.— *Мулла абзыйлар янында чәй эчте дә минем янга, мал өенә, йокларга керде.* Т. Гыйззәт.

◇ **Мал итү** — яраклы, файдалы хәлгә китерү. *Печәнне мал итим дип Халикъ чабар, маллыктан чыгарыйм дип Малик чабар.* Мәкаль. **Мал җанлы** — байлык, акча яратучы, байлык өчен тырышучы.— *Син яшьтән үк тынычсыз, мал җанлы идең.* Т. Гыйззәт.

МАЛАЙ *и.* 1. Яңа туган яки кече яшьтәге, яшүсмер ир бала. *Гөлбаһар абыстай тагын бер малай тапты.* М. Гали. *Малайлар җиңел атлыйлар, бөтерелеп йөриләр, алар өчен ат белән эшләү, ат янында булу үзе бер бәйрәм иде.* Г. Бәширов. || Ата-анага мөнәсәбәттә: ул, ир бала. *Киявең әйтсә, ишек бавын тотарсың, Малаең әйтсә, бишек бавын тотарсың.* Мәкаль. *Көтүче Шәгаеп үзенең ике малае белән - - - мал көтеп йөри иде.* М. Гали.

2. *сөйл.* Гомумән сөйләүчедән яшьрәк булган ир кеше.— *Яратмыйм шул малайны! Нәрсәгә икән? Чынлабрак уйлап карасаң, бәлки, ул хәтле эшкә дә егет түгелдер.* Ш. Камал. || *сөйл.* Дәрәҗәсе яки эш тәҗрибәсе белән түбән яки җитди булмаган, беркатлы кеше турында.— *Мин, үземнең исемемне әллә нинди малайлардан таптатмас өчен, һәртөрле юлга керергә хәзер.* М. Фәйзи.

3. *иск.* Хезмәтче.— *Малай! Кая миңа бер стакан чәй, ике сумса китер әле.* Г. Камал. || Берәр төрле һөнәргә өйрәнүче, өйрәнчек. *Атасы аны бер кибеткә малай итеп бирде.* К. Тинчурин.

4. *сөйл.* Бер-береңә (шул исәптән хатын-кызларга да) тәкәллефсез һәм дусларча мөрәҗәгать итү сүзе. *Икенче бер егет әкрен генә сызгырды да: „Шәфикъ, малай, синме?“ — дип кычкырып, аның кем икәнен дә сорап куйды.* М. Гали.— *Дөньяны җимерәбез, малай, хәзер чит патша җирләрендә йөрибез.* Г. Ибраһимов.

◇ **Малай актыгы** — гадәттә малайларны, егетләрне, яшьрәк ирләрне шелтәләгәндә, тиргәгәндә кулланыла. *Бу малай актыкларын нишләтеп тотасыз сез үз авылыгызда?* М. Әмир.

***МАЛАЙЛА'РЧА** *рәв.* Малайларга хас булганча, малайлар кебек. [*Хәйдәр*], *малайларча бер җиңеллек белән аксый-аксый, кайтыр юлыннан Нәфисәләр станына таба борыла.* Г. Бәширов. || *күч.* Төптән уйламыйча, җиңелчә генә. *Ул чактагы эзләнүләрем, турысын гына әйткәндә, бигрәк малайларча булган икән минем.* Р. Төхфәтуллин.

МАЛАЙЛЫК *и.* 1. Малай яшендәге чор, малай чак еллары. *Малайлыктан уздык бугай инде, Булмасак та әле ир-ага.* Гәр. Рәхим. || *с. мәгъ.* Малайларга,

малай яшендәге чорга хас. *Малайлык шуклыклары чыгып бетмәу.*

2. Кемдә дә булса хезмәтче булу эше. *Зариф хәзрәттә малайлыкта торган Шаһбаз, --- күрше авылга барып, карт чувашка дуңгыз көтәргә яллана.* Г. Нигъмәти. — *Мортаза берәүне дә үзенә малайлыкка ялламый.* Ә. Фәйзи. || Берәр төрле һөнәр алу өчен өйрәнчек булу эше. — *Кара аны, миңа тырышып хезмәт итсәң, үзеңне малайлыктан приказчиклыкка күчерермен.* А. Расих.

МАЛАЙ-САЛАЙ, МАЛАЙ-ШАЛАЙ *җый. и. сөйл.* Төрле яшьтәге малайлар, яшүсмерләр. — *Бүгенге спектакльгә малай-салайларны кертмиләр.* С. Баттал. [*Җыелышка*] *алдан килүчеләрнең күбесе укучылар, яшь малай-шалай һәм кызчыклар булып, берәм-сәрәм олы кешеләр дә җыйнала башладылар.* Ш. Камал. || Кемнең дә булса өлкән яки дәрәҗәле кеше икәнлеген искәртү өчен кулланыла. — *Мин малай-шалай түгел сиңа, Вәли әнем.* С. Рафиков.

МАЛАЙСЫТУ *ф.* Малай дип, яшь дип карау, балага санау. *Иң әлек* [*минем янга больницага*] *Алеша белән капитан килде. Бигрәк малайсытканнар: шоколадлар, печеньеләр, конфетлар төяп килгәннәр.* Р. Төхфәтуллин. || Яшь, тәҗрибәсез дип карау, беркатлыга санау. [*Мусага*] *иптәшләренең хәтере калды. Бигрәк малайсыта инде. Ләкин әчләренә йоттылар.* Ш. Маннур.

МАЛАЙЧАК *и.* Малай яшендәге чор, малайлык еллары. *Малайчак белән егетчак чиген сизми дә калдык.* А. Гыйләҗев.

МАЛАЙЯЛЫ *и.* Малайя архипелагы утрауларында һәм Малакка ярымутравында яшәүче халыклар һәм кабиләләр төркеменең атамасы; шул халык яки кабилә кешесе. *Кара чәчле ябык малайялы көймә койрыгына баскан да, учларын авызына куеп, капитанга нәрсәдер кычкыра.* Р. Мостафин.

МАЛАХАЙ *и.* Мехтан тегелгән колакчын бүрек. *Малахайны салып куеп, Бөклән утырып аякны, Исмай тыңлый, Ибрай тыңлый, Бар да киңәшне яклый.* М. Җәлил. *Өстенә җылы күн тужурка, башына зур йонтач малахай кигән Гафур ишекне хуҗаларча киң ачып кайтып керә.* Р. Ишморат. || *с. мәгъ.* Мехтан колакчынлы итеп тегелгән. *Миңнурый карт, иске сары туның киеп, малахай бүрегенең колакларын тырпайтып, мич янында --- тын гына утыра.* А. Шамов.

МАЛАХИТ *и.* Ачык яшел төстәге минерал (ювелир әйберләре эшләү яки бакыр алу өчен чимал буларак файдаланыла). *Урал --- малахит, яшма һ. б. лар белән бөтен дөньяда дан тота.* СССР физ. геогр. || *с. мәгъ.* Малахит төсендәге. [*Һади абзый*], *малахит яшел күзләре белән елмаеп, туп-туры карап торды, кул бирде.* Н. Исәнбәт.

МАЛБАГАР *и. сөйл.* Мал караучы.

МАЛИК *и. иск.* Ия, хуҗа. *Әгәр миңа җырлар яр-дәм итмәсә, --- туган телебезне сөймәк кеби бер олуг нигъмәткә малик була алыр идеммени?* Г. Тукай.

МА|ЛИЦА *и.* Төньякта яшәүче халыкларда: болан тиресеннән йонын эчкә калдырып, башлыклы, бияләйле итеп тоташтан тегелгән тышкы кием.

МАЛКУАР *и. к.* эшкуар. [*Бу шәһәрдә*] *башлыча чиновниклар, дәүләт учреждениеләре кешеләре, файдалы дәүләт заказлары алырга тырышучы төрле малкуарлар --- яши.* Дөнья кис. геогр.

МАЛКУРА *и. диал.* Мал ябу өчен тышкы абзар, киртә абзар; утар.

МАЛЛЫ *с.* 1. Малга (1 мәгъ.) бай, малы күп булган; барлыклы, хәлле. *Фермаң маллы булса, эшең җайлы булыр.* Н. Исәнбәт.

2. Мул тормышлы, бай; малы (2 мәгъ.) күп булган. *Сәхәү карт яшь чагында бик тәүфыйксыз кеше булган имеш. Кәлимулла исемле зур маллы картның төпчек улы булганга күрә, иркә үскән ди.* М. Әмир. [*Җәләлгә*] *зур байдан маллы кыз алырга да юл ачылган була.* Г. Ибраһимов.

МАЛЛЫК *с.* 1. Малга (1 мәгъ.) җитәрлек, мал өчен махсус. *Маллык азык хәзерләү.*

2. *и. мәгъ.* Мал (1, 2 мәгъ.) буларак, файдалылык, әһәмиятлелек дәрәҗәсе. *Кәҗәнең маллыгы юк.* Мәкаль.

◇ **Маллыктан чыгару** — яраксыз, файдасыз хәлгә китерү.

МАЛ-МӨЛКӘТ *җый. и.* Шәхси милек, байлык; аерым хуҗалыкта тупланган тормыш кирәк-яраклары. *Вәлишиннең башына бер уй килде: барлык мал-мөлкәтне, алтынга әйләндереп, революция җиле барып житмәслек урынга күчерергә кирәк.* К. Нәҗми. *Авылда байлар беткән, аларның мал-мөлкәтләре колхозга күчкән.* Ә. Еники.

МАЛ-МӨЛКӘТЛЕ *с.* Шәхси хуҗалыгы җитеш, хәлле, бай. *Мал-мөлкәтле кешеләрнең барысы да диярлек --- дачаларга сыздылар.* К. Нәҗми. — *Син теләнчегә шундый мал-мөлкәтле хатын түгел, хәтта урамда теләнеп йөри торган убырлы карчык та чыкмаячак.* А. Шамов.

МАЛСЫЗЛЫК *и.* Мал аз булу хәле; ярлылык, фәкыйрьлек. [*Солдатларны*] *илләрендә авыр тормыш, җирсезлек, малсызлык, төрле яктан җитешсезлек каршы алырга көтеп торгандай күренде.* М. Гафури.

МАЛ-ТУАР *җый. и.* Йорт хайваннары, терлек. — *Уңыш начар булу сәбәпле, --- эш хайваннарыннан башка мал-туарны беркадәр киметергә туры килер.* Ш. Камал. [*Нурулла*] *яшьтән үк абзар-кура, мал-туар арасында чуалырга яратты.* А. Гыйләҗев.

МАЛЧЫ *и.* Мал асраучы. *Малчы мал карар, балчы бал карар.* Мәкаль. *Малчы кулы майда булыр.* Мәкаль.

МАЛЧЫЛЫК *и.* Авыл хуҗалыгының терлек үрчетү белән шөгыльләнә торган тармагы; мал асраучылык.

МАЛЬТУЗИАНЛЫК *и.* Капитализм шартларында хезмәт ияләренең фәкыйрьлектә яшәвен социаль сәбәпләр белән түгел, ә халык санының бик тиз артуы белән аңлата торган реакцион теория (авторы — инглиз буржуаз экономисты Мальтус).

МАЛЬТУЗИАНЧЫ *и.* Мальтузианлык тарафдары.

МА|ЛЬВА *и. бот.* Озын сабаклы һәм эре чәчәкле декоратив үлән үсемлек; тырнак гөл. *Мальваны орлыктан үрчетәләр, --- яхшы ашланган туфракта күп чәчәк ата.* Йорт эшләре.

МАЛЯР *и.* 1. Бүлмә, биналарны буяучы, агартучы эшче. *Иделне чыгып, бераз киткәч тә, безгә бер грузовик ремонт эшчеләре: балта осталары, ташчылар, малярлар очрады.* Г. Гобәй. [*Зөфәр*], *малярлар китертеп, капка-коймасын сарыга, өй түбәсен яшелгә буятып җибәрде.* Ә. Еники.

2. *сөйл. кимс.* Начар рәссам яки язучы турында. [*Вәсилә язучыга:*] *Сез, малярлар, ясап куйган тоташ бәхетне, авыр аякларым белән ерып, ничә еллар буена мин аны эзләп йөрдем.* Ф. Хөсни.

МАЛЯРЛЫК *и.* Маляр эше, һөнәре. *Малярлыкка өйрәнү.*

МАЛЯРИ|Я *и. сөйл. к.* бизгәк. *Әхмәтҗан туберкулез белән түгел, ә малярия белән генә авырган иде.* А. Шамов.

МАМАЛЫ'ГА *и.* Кукуруз онынан пешерелгән куе ботка, боламык.

МАМЗЕЛЬ *и. гади с.* **1.** *к.* мадемуазель. *Шәрифҗан атын туп-туры [буржуйкалар] өстенә борды: — Мадамнар, мамзельләр, юл бир!* И. Гази.

2. Җилбәзәк хатын-кызга карата әйтелә. *Леонид Абрамович, мыскыл катыш елмаеп, Нюраның күзләренә карады: — Әшләр ничек, мамзель.* Р. Ильяс.

МА'МОНТ *и.* Бозлык чорында яшәгән озын йонлы, дугаланып торган ике озын казык тешле һәм хортумлы, филгә охшаш зур гәүдәле хайван. *Инде күптән үткән, диләр, Мамонтлар торган заман. Мамонтлар күптән бетсә дә, Бюрократ яши һаман.* Н. Дәүли.

Мамонт агачы — Төньяк Америкада үсә торган ылыслы гигант агач; *к.* секвойя.

МАМЫК *и.* **1.** Мальвалар семьялыгыннан көньякта игелә торган берьеллык үсемлек. *Сулда, карлы дала кебек агарып, мамык басуы күренә.* Д. Аппакова. *Үсәр чүлдә мамык, виноград, Саран сахра ямьгә төренер.* Ш. Мөдәррис.

2. Шул үсемлекнең җеп, целлюлоза һ. б. хәзерләү өчен кулланыла торган орлык сүсе. *Мамык җыю. Дәүләткә мамык тапшыру.* || Шул сүснең махсус эшкәртелгән нәфис, йомшак массасы (медицинада, көнкүрештә кулланыла). *Хәлим [аягының] суелган җирен мамык куеп бәйләде дә яланаяк эшләде.* Г. Гобәй. *Мамыклар белән сырдырдым бишмәтемнең билләрен.* Җыр. || *с. мәгъ.* Шундый сүстән эрләнгән. *Нәгыймә --- сәке астыннан калтырчасын алып шүре ясады; тырупчага чолгаган мамык җепләрен рәтләде.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Шундый сүснең җебеннән тукылган, бәйләнгән. *Мамык тукыма.* □ *Җиделе лампа, мамык филтә Яна кибет алдында.* Җыр.

3. Кайбер хайваннарда эре йон астындагы кыска, бик йомшак, нәфис йон (капламы). *Дөя мамыгы.* □ *[Кызның] өстендә куян мамыгыннан калын итеп, күпертеп бәйләнгән, җылы һәм йомшак икәнлеге әллә кайдан күренеп торган ап-ак кофта иде.* М. Әмир. *[Ярминкә көннәрендә] хатын-кыз кәҗә мамыгыннан бәйләнгән шәлен, биш билле яңа сатин тышлы бишмәтен кия.* А. Расих. || *с. мәгъ.* Шундый йонның җебеннән бәйләгән. *Мамык шарф. Мамык перчатка.* □ *Мамык шәлең, кызым, җылымы? Җылы булса, катлап урама.* Җыр.

4. Кошлар тәнендәге нәфис, йомшак йон. *Каз мамыгы.* □ *[Төлке Чәүкәгә:] Карлыгач балаларына ана бул, аларны җылы мамыгың белән җылыт.* Г. Тукай. *Кошчык малайның уч төбен рәхәт кытыклый — яңа чыгып килгән мамык канатлары кыймылдый иде.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Шундый йон тутырып ясалган. *Мамык түшәк.* □ *Сафия абыстай кунакка --- мамык мендәр салып, урын хәзерләп бирде.* А. Шамов.

5. Кайбер үлән үсемлекләрдә һәм агачларда җил белән коела, таратыла торган нәфис төкләр, җепселләр. *Тузганакбаш мамыгы.* □ *Тал-тирәкләр мамык [коя].* Х. Туфан.

6. *күч.* Яңа яуган йомшак кар турында. *Таңнан башланган кар туктамады, яуды да яуды. Агачларның ботаклары яңа йомшак ак мамыкларга төренделәр.* Г. Ибраһимов.

Мамык бете — *к.* мамыкашар.

◇ **Мамык итү** — йомшарту, йомшак итү.— *Бер кантарын калдырмый тырмала! Тет үзен, мамык ит! Үзебезнең җир!* И. Гази.

МАМЫКАШАР *и. зоол.* Кошларда һәм имезүче хайваннарда тереклек итүче канатсыз паразит бөҗәк; *русчасы:* пухоед.

МАМЫКБАШ *и. бот.* Орлыклары чәч сыман озын, ялтырап торган ак йон бөртекләренә урнашкан саз үләне; *русчасы:* пушица. *Мамыкбаш үләннәре чәчәктә утыра.* Каз. утл.

МАМЫКЛАНДЫРУ *ф.* Мамык кебек итеп йомшарту, йомшак хәлгә китерү. *[Каты сүс бауны, таратып], мамыкландырганчы тетәбез.* Г. Гобәй.

МАМЫКЛАНУ *ф.* **1.** Мамык йон үсү, мамык белән капланы (кошларда, кайбер хайваннарда, үсемлекләрдә). *Куяннар әрсезләнеп үрчеделәр, зурлары торган саен итләчләнә, мамыкланып һаман кабара бардылар.* М. Шабай. *Көзен исә кылган, мамыкланып, чал төскә керә һәм дала кар белән капланган төсле тоела.* Каз. утл.

2. Йомшару, бик йомшак, мамык сыман хәлгә килү. *Кабарып, мамыкланып торган ярым бөдрә чәчләре тегелгәй дә ачык, сөйкемле, гел көлемсерәүле йөзенә тагын да күркәмлек бирәләр иде.* З. Бәшири.

3. Мамыкка (2—4 мәгъ.) буялу (кием турында).

4. *күч.* Материаль кыенлыктан чыгу, җитешле, хәлле тормыш белән яши башлау. *Икәүләп эшләп, мамыклана башлагач кына, [Мәрьям үлеп китте].* Ә. Еники.

МАМЫКЛЫ *с.* **1.** Мамыкка (1, 2 мәгъ.) бай, мамык күп булган. *Мамыклы Төркмәнстан.*

2. Мамык (2—4 мәгъ.) тутырылган, эченә мамык салып сырылган һ. б. *Кулы юк — күлмәк кия, Кош түгел — мамыклы, Мамыгы эчтә, Кирәк була кичкә.* Табышмак. || Мамык төкләре ябышкан, мамыкка буялган. *Өсте-башы мамыклы.*

3. Мамыкланып, кабарып торган. *Беренче булып төлке сайлый койрыкны: — Миңа менә шунысын, мамыклысын, йонлысын, — ди.* А. Алиш.

МАМЫКЧЫ *и.* Мамык үстерү белән шөгыльләнүче; мамык хуҗалыгында эшләүче. *Тажи нугай менә бүген дә ике кышлакта булды, мамыкчылар белән очрашты.* Каз. утл.

МАМЫКЧЫЛЫК *и.* Авыл хуҗалыгының мамык үстерү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Мишәр сәүдәгәрләре, --- тере куйлар җыеп, аларны көтү-көтү итеп, мамыкчылык белән көн күрә торган Фирганә тарафына җибәрәләр.* З. Бәшири. || *с. мәгъ.* Авыл хуҗалыгының шундый тармагына караган. *Мамыкчылык совхозы. Мамыкчылык районнары.*

МАМЫК-ҖЕП *с. к.* киҗе-мамык **1.** *Мамык-җеп тукымалар җитештерү.*

МАНАРА *и.* **1.** Мәчет түбәсендә яки аның янында гадәттә түгәрәк, дүрт яисә күпкырлы тар конус рәвешендә эшләнгән биек корылма (мәзин шунда менеп азан әйткән, мәхәллә халкын намазга чакырган). *Агачлар арасыннан мәчет манарасы күренеп тора.* И. Гази. *Мәзин өйдә булмаган чакларда, Яуми, манарага менеп, азан да әйткәли.* К. Тинчурин. || Чиркәү түбәсендә яки аның янында чаңнар элү өчен (гадәттә цилиндрик яки кырлы формада эшләнгән) тар биек корылма. *Шәһәр өстеннән бердәнбер чиркәүнең ничектер җимерелми калган манарасы калкып тора.* Г. Бәширов.

2. Гомумән шундый формадарак эшләнгән һәртөрле тар биек корылма; башня. *Сөембикә манарасы. Күзәтү манаралары.* □ *Эйфель манарасы — җир шарында кеше кулы белән эшләнгән биек ноктаның иң биеге.* Г. Гали.

МАНАРАЛЫ *с.* Манаралап эшләнгән. *Манаралы мавзолей.* □ *Болгаргача заманнарда ук халык калын-калын стеналы һәм манаралы хәрби пулатлар, ныгытмалар торгыза.* Каз. утл.

МА'НГО *и. бот.* **1.** Тропик урманнарда үсә торган җимеш агачы.

2. Шул агачның саргылт-яшел тәстәге хуш исле татлы җимеше.

МАНДАРИН *и.* 1. Көньякта үсә торган мәңге яшел җимеш агачы.

2. Шул агачның әфлисунга охшаш юка кабыклы, хуш исле татлы җимеше. [*Марат*] *кичтән мандарин ашап ятты.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Мандариннан хәзерләнгән. *Мандарин вареньесы.*

МАНДАТ *и.* 1. Нинди дә булса бер эшкә вәкаләтле булуны яки эш йөкләтелгәнлекне раслый торган таныклык. *Депутатлык мандаты.* □ *Ишек киң итеп ачылган, аның ике ягында ике кызылармеец басып тора. Алар* [*конференциягә*] *керүчеләрнең --- мандатларын тикшереп торалар булса кирәк.* А. Шамов.

2. Колониаль яки экономик һәм политик хәле йомшак кечкенә илләр белән идарә итү яки анда тынычлык урнаштыру өчен икенче бер илләргә халыкара оешма (Милләтләр Лигасы, БМО) тарафыннан бирелгән хокук. *Куркынычсызлык советы БМОның Кипрда тынычлыкны саклау өчен җибәрелгән кораллы көчләре мандатын 1969 елның 15 июненә кадәр озайту турында карар кабул итте.* Соц. Тат.

Мандат комиссиясе — съездларда, конференцияләрдә, хезмәт ияләре депутатлары Советы сессияләрендә катнашучыларның вәкаләтлекләрен тикшерү өчен сайлап куела торган орган. [*Гайфуллинны*] *мандат комиссиясенә рәис итеп сайладылар.* Г. Ибраһимов.

МАНДАТЛЫ: мандатлы территорияләр — беренче бөтендөнья сугышында җиңеп чыккан илләргә (Англиягә, АКШка, Франциягә) Милләтләр лигасы мандаты нигезендә идарә итү өчен бирелгән әлеккеге Германия колонияләренең һәм Төркиягә бәйле кайбер биләмәләрнең гомуми атамасы.

МАНДОЛИ'НА *и.* Озынча түгәрәк корпуслы итеп агачтан эшләнгән, дүрт пар кыллы музыка коралы. *Галия медиаторны --- мандолинаның кыллары арасына кыстырып куйган.* А. Расих.

МАНДОЛИНЧЫ *и.* Мандолинада уйнаучы музыка остасы. *Бу вакытта инде Исмәгыйль Һилалов зур осталыкка ирешкән атаклы мандолинчы булып таныла.* Ж. Фәйзи.

МАНЁВР *и.* 1. *хәрби.* Сугыш вакытында гаскәрнең яки флотның дошманга һөҗүм итү өчен җайлырак урынга күчүе яисә тупланuы. *Полк командиры --- шундый маневр ясады — дошман атлылары кинәт ярым алка эчендә калдылар.* А. Шамов. *Бу --- һөҗүм дошманны алдау өчен оештырылган һәм безнең өчен мөһим булмаган юнәлештәге маневр гына иде.* Каз. утл. || Гаскәрнең яки флотның сугыш шартларына якынлаштырылган обстановкада тактик өйрәнүләре. *Дөрес, маневрлар уен кебек, ләкин алар — Зур җиңүгә бару юллары.* Һ. Такташ. || *с. мәгъ. к.* маневрчан 1. *Маневр сугышында фронт сызыгы йөгерек ат тизлеге белән үзгәртелгәнлектән, тирә-яктан күзне алмыйча карап торабыз.* Ш. Усманов.

2. *күч.* Оста хәрәкәт. [*Гарифка*] *ияручеләр дә тиз табылды, бер-бер артлы өч кеше, шундый ук маневрлар ясап, көймәгә керделәр.* Ш. Камал. || Хәйлә; хәйләләү, алдау максаты белән кулланылган алым. *Искәндәрнең бу маневрын барысы да беләләр. Бу аның актив арасындагы оппортунизм җәясен тартып карау маневры иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

3. *махс.* Тимер юл станциясендә поездлар төзү өчен вагоннарны юлдан юлга күчереп йөртү. *Станциядә маневр ясап йөрүче паровозның өзек-өзек сызгыртулары --- ишетелә.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Шул эшне башкару өчен билгеләнгән. *Тимер юл станциясендә чәрелдәп паровоз кычкыра. „Маневр паровозы", дип уйлый Якуб.* И. Гази.

4. Хәрәкәт юнәлешенең үзгәреше, курс алмашыну (корабль, самолет һ. б. турында). *Капитан Дурашин, маневр ясап, пароходны әле һаман да бер алга, бер артка йөртә иде.* Х. Садрый. *Маневр ясарлык булмады, күрәсең, хатын, сигнал бирә-бирә, машинаны арты белән алып бара башлады.* Г. Гобәй.

МАНЁВРЛАУ *ф.* Хәрәкәт юнәлешен үзгәртү, тиешле юнәлеш бирү. *„Союз-4" һәм „Союз-5" космик корабльләрен маневрлау.*

МАНЁВРЧАН *с.* 1. Маневрлардан (1 мәгъ.) киң файдаланып алып барыла торган; *киресе:* позицион. *Маневрчан сугыш. Маневрчан оборона.*

2. Хәрәкәт юнәлешен бик тиз үзгәртә алу сәләтенә ия булган; хәрәкәтчән. *Маневрчан космик корабль.*

МАНЁВРЧАНЛЫК *и.* Маневрчан булу сыйфаты. *Космик корабльнең маневрчанлыгын сынау.*

МАНЕЖ *и.* 1. Атка атланып йөрү, ат өстендә күнегүләр үткәрү өчен җайлаштырылган мәйданчык яки бина. *Ташбай --- башкалар белән атлар тазартырга бара, ат өстендә йөри, манежда чаба иде.* Ә. Айдар.

2. Цирк аренасы. *Манежда акробатлар чыгышын карау.*

3. Ветеринария пунктында авыру хайваннарны карау һәм дәвалау процедуралары үткәрү өчен махсус эшләнгән мәйданчык. *Рәхим ветеринария шифаханәсенә килеп җитте. Үз бүлмәсенә кереп халатын киде һәм манежга чыкты.* А. Расих.

МАНЕКЕН *и.* 1. Кием күрсәтү өчен агачтан, папьемашедан кеше зурлыгында ясалган курчак. [*Гамбәр*] *егет алдында үзен гүя --- витринадагы манекен шикелле хис итә иде.* Ә. Еники. *Зур бер кибет яныннан узганда, Сажидә кинәт туктады да тәрәзә арасына куелган ир кеше манекенына төртеп күрсәтте.* М. Галәү. || Киемне үлчәп, карап тегү өчен кеше гәүдәсенә охшатып ясалган калып, фигура.

2. *махс.* Кешенең киемен, гәүдә торышын төрле хәлдә рәсемгә төшерү өчен кул-аяклары хәрәкәтләнә торган агач курчак.

МАНЕКЕНЧЫ *и.* 1. Манекеннар ясаучы.

2. Әзер киемнәр магазинында киемне үз өстенә киеп күрсәтүче хезмәткәр.

МАНЕР *и. сөйл. к.* манера. *Сөйләм теленнән беркадәр аермалы булган бу күренешләрне халыкның җырны беркадәр шигъри музыкальлеккә күтәрү, аны әдәби стильләштерү манеры дип карарга кирәк.* Н. Исәнбәт.

МАНЕ'РА *и.* 1. Үз-үзеңне тоту рәвеше, үз-үзеңне тотудагы тышкы формалар (кыланышлар); гадәт. [*Хөснетдин*] *ике-өч ел гына әлек солдатта булган икән. Әле дә аның кайсыбер кыланышларында андагы манералар күренгәли.* Ш. Камал.

2. Ижади эштә аерым авторларга хас алымнар, характерлы үзенчәлекләр җыелмасы. *Сириннең бу* [*„Булмый, булмый"*] *шигыре, һичшиксез, М. Гафури иҗат манерасына якын иде.* Х. Госман. || Кемгә дә булса хас берәр төрле индивидуаль үзенчәлек. [*Ф. Әмирхан*ның] *сөйләү манерасы, сүзләрне оста сайлавы --- барлык игътибарымны үзенә тартты.* А. Шамов.

МАНЖЕТ *и.* Күлмәк яки блуза җиңенә эләктереп яки тегеп куела торган җиң очы (җиң очы кайтармасы). *Кибетнең тышы да, эче дә күз явын алып тора. --- Сатучылар да ак яка һәм манжетлардан гына.* М. Шабай.

МАНЖЕТЛЫ *с.* Җиң очына манжет беркетелгән. *Сүзне җитү чәчле, ак якалы, манжетлы яшь егеткә бирделәр.* А. Расих.

МАНЗАРА *и. кит.* 1. Табигать күренеше, пейзаж. *Заполярьеның ялангач таулары манзарасына кырыс*

матурлык биреп, биек төз наратлар үсә иде. Г. Әпсәләмов.

2. Нинди дә булса күренеш, вакыйга. *Яшьлегемнең бу дәвереннән бик ачы тойгы вә тәэсирләр, кайгылы манзаралар хәтерлим.* Ш. Камал. *Яңа гына күршеләрен [солдатка] озаткан вакыттагы манзара аның күз алдына килде.* М. Гафури.

3. *иск.* Сәхнә әсәрендә аерым пәрдәнең төгәлләнгән кисәге, күренеше, картинасы. *Пьеса бер пәрдәдә, ике манзарада.* Г. Камал.

МАНИГЪ *и. иск.* Каршылык, тоткарлык, комачау. *Вакытында үз фикерләремне язарга әллә нинди манигълар булды.* Г. Тукай.— *Юлдагы манигъларны тибеп аударmый торып, теләккә ирешеп булмый.* М. Фәйзи.

МАНИКЮР *и.* 1. Кул тырнакларын махсус чистарту һәм лак белән буяу. *Маникюр ясату.* || *с. мәгъ.* Маникюр ясау өчен хезмәт итә торган. *Маникюр кайчысы.* || Лакка буялган, ялтыратылган (гадәттә озын) тырнаклар турында. *Шаукымга бирелеп, без дә Сүктек тар балакларны, Чәчләрне ... маникюр белән Бизәлгән бармакларны.* Ш. Галиев.

2. Тырнакларны буяу, ялтырату өчен махсус лак (гадәттә алсу, кызыл, куе кызыл һ. б. ш. төсләрдә була). [*Ханым*], *күгәрчен тәпие төсле маникюр сыланган тырнаклары белән чеметеп, пенснесен салды.* Ш. Хөсәенов.

МАНИКЮРЛАУ *ф.* Махсус чистарту һәм маникюр (2 мәгъ.) белән буяу (тырнаклар турында). [*Кыз*] *тырнакларын бик оста маникюрлаган, килешле ак халат кигән.* А. Шамов.

МАНИКЮРЛЫ *с.* Маникюр (1 мәгъ.) ясалган. *Сәхнәдәге өстәл артында өч кеше — аксыл мыеклы галим, яшь чырайлы галим, сары чәчле, маникюрлы, кып-кызыл иренле чибәр кыз утыра.* М. Мәһдиев.

МАНИКЮРЧЫ *и.* Маникюр (1 мәгъ.) ясаучы оста.

МАНИ'ЛОВЧЫЛЫК *и.* Буш хыялга бирелүчәнлек.

МАНИЛЬ *и.* Күпьеллык тропик үсемлек (бананның бер төре) яфраклары җепселләреннән алына торган тупас сүс, пәҗе. *Трослар төрле нәрсәләрдән эшләнәләр: маниль, кокос, һинд сүсе, нейлон, корыч, киндер, мамык, капрон...* Р. Мостафин.

МАНИОК *и. бот.* Сөтлегәннәр семьялыгыннан мәңге яшел тропик куак (крахмалга бай эре бүлбеле тамырларыннан, киптереп, туклыклы он хәзерлиләр). *Алар басуда маниок һәм су бананы утырттылар.* Каз. утл.

МАНИПУЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. Кул белән яки телдән, хәтердән башкарыла торган эштә нинди дә булса алым, катлаулы хәрәкәт. *Мәдинә — Дина — Надя. Бу исемнәр берсеннән икенчесе килеп чыга, бары тик иҗекләрен генә алмаштырырга һәм „нә“ иҗеге белән манипуляция ясарга кирәк.* С. Баттал.

2. Оста алдау, астыртын хәйлә, ялган эш.— *Шулай да бу кызны күзәтергә кирәк. Манипуляция булмасын.* Т. Гыйззәт.

МАНИПУЛЯ'ТОР *и.* Төрле әйберләр белән оста манипуляция ясаучы цирк артисты — фокусчы.

МАНИФЕСТ *и.* 1. Илдәге зур вакыйга уңае белән югары властьның бөтен халык исеменә чыгарган язма мөрәҗәгате.— *Ипташлар, мөселман агай-энеләр, патша манифест биргән. --- Ләкин моңа алданырга ярамый.* Г. Ибраһимов. *Пугачев манифестын тыңлаган крестьяннар, төркем-төркем булып, бу отрядларга кушылалар.* Каз. утл.

2. Политик партиянең яки иҗтимагый оешманың программа характерындагы язма мөрәҗәгате, өндәмәсе. *Коммунистлар партиясе манифесты. Тынычлык өчен көрәш манифесты.*

3. Нинди дә булса әдәби юнәлешнең, язучылар яки художниклар төркеменең иҗат принциплары турында язмача бәяны, белдерүе. *Имажинистлар манифесты.*

МАНИФЕСТА'ЦИЯ *и.* Нинди дә булса политик вакыйгага карата теләктәшлек яки протест белдерү йөзеннән киң масса катнашында үткәрелә торган демонстрация. *Берничә кеше сөйләгәч, „Интернационал“ җырланып, манифестация тарала башлады.* М. Гафури.

МАНИФЕСТАНТ *и. кит.* Манифестациядә катнашучы. *Ул арада урамны буып алган манифестантлар тагы да катырак кычкырырга, сызгырырга тотындылар.* А. Расих.

МА'НИЯ *и.* 1. Аңның, хисләрнең берәр шикле идея, уй тирәсенә тупланuына бәйләнешле авыру халәте. *Әхмәтнең рухында яңадан бер маниягә юл ачылган иде: --- ул [үзен] үтерүләреннән курка башлаган иде.* Г. Газиз.

2. *күч.* Нәрсәгә дә булса гадәттән тыш һәвәслек, бирелүчәнлек. *Марка коллекцияләре җыю маниясе.*

МАНМА: манма су (булу) — бик нык, суга тыгып алган кебек юешләнгән, чыланган (булу). *Аның өсте манма су.* Г. Әпсәләмов. *Киемнәр манма су була, аякларга күтәрә алмаслык балчык ябыша.* А. Шамов. **Манма суга бату** — *к.* манма тир булу. *Уянганда Зыя манма суга баткан, ... йөрәге бөтен тәнен дерелдәтә иде.* Г. Ибраһимов. **Манма суга әйләнү** — бик нык, суга тыгып алган кебек юешләнү, чылану. *Көн сәген явып бөтен киемнәрне манма суга әйләндергән яңгыр кичкә таба туктады.* Каз. утл. **Манма тир булу (тиргә бату, төшү)** — бик каты тирләү. [*Сәфәргали*] *манма тиргә баткан айгырда, тарантас түренә кырын ята биреп, авыз эченнән нидер җырлагандай итеп кайтып* [*керде*]. Ф. Хөсни. *Бер җирдән икенче җиргә атылып йөргән Степан инде үзе дә манма тиргә төшкән.* М. Шабай.

МАНМАЛЫ *с. диал.* Нәрсәгә дә булса манылган яки нәрсә дә булса (алтын, көмеш) йөгертелгән. *Чәч кенәләремнең көдрәсенә Манмалы тәңкәләр үрермен. Минем җан гынаем тынмаса, Җиңгәкәем, синнән күрермен.* Җыр.

МА'ННА *и.* Библия мифологиясендә: күктән төшкән ашамлык. *Алла [12 мең кешене] маймылга әверелдерә. Беләсезме нәрсә өчен? Тегеләр бу манна белән бытбылдык туйдыра башлаган.* Г. Гобәй.

МАННЫЙ *и.* Бик вак бөртекле бодай ярмасы. *Магазинга манный каптарту.* || *с. мәгъ.* Шундый ярмадан әзерләнгән. *Манный пудинг.* □ — *Балага манный ботка пешергән идем, шуны ашатып алыйм әле.* Т. Гыйззәт.

Манный ярмасы — *к.* манный.

МАНО'МЕТР *и.* Йомык савыт эчендәге сыеклыкның яки газның басымын үлчәү приборы. *Сыекчалы манометр. Пружиналы манометр.* □ *Бәдри пар казанын[дагы] манометрга ымлады: — Ул монда нәрсә күрсәтә икән?* И. Гази.

МАНОМЕ'ТРИК *с.* Манометр ярдәмендә башкарыла торган. *Манометрик үлчәү.*

МАНСА'РДА *и.* Чарлакта авыш түбәле яки авыш стеналы итеп эшләнгән торак бүлмә. *Ул, ялгыз үзе генә, Арча кырындагы бер мансардада тора иде.* А. Расих.

МА'НСИ *и.* Угро-фин телләре группасыннан Ханты-Манси милли округында яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе.

МА'НТИЯ *и.* 1. Плащ сыман киң, итәге җиргә тиярдәй озын кием.

2. *зоол.* Кайбер умырткасыз хайваннарда тире катлавы, ябынча. *Моллюскларның характерлы органнары — мантия һәм аяк.* Зоология.

МАНТО *и.* Иркен итеп (гадәттә мехтан) тегелгән хатын-кыз пальтосы.— *Безнең мех ул — мех, ичмасам. - - - Мантоларга гына кара син безнең. Күзләрең чагылыр.* Р. Ишморат. *Ул ак берет кигән, кара манто.* Г. Әпсәләмов.

МАНТУ *ф. сөйл.* 1. Сәламәтләнү, тазару, рәтләнү, хәл керү.— [*Минем картым герман сугышыннан*] *яраланып кайткан иде, һаман мантымый.* А. Шамов. [*Әби*] *озын муенлыма, үтә ябык, кечкенә гәүдәмә карап тора да: — Бигрәк күркә чебеше инде, мескенем, мантыса гына ярар иде, — ди.* Г. Гобәй.

2. Эш, тормыш уңышлы бару; уңу, уңай нәтиҗәгә ирешү. *Ашыккан кыз киявүгә барса да мантымас.* Мәкаль.— *Безгә бит вак тиредән бер бүрек эче җыйганга ике тиен, - - - бүрек тышын кисеп теккән өчен бары өч тиен түлиләр. Аның белән ничек мантыйсың, — диде Гөлгенә түти.* М. Гали.— *Моңарчы әле Шәйморат абзагыз белән дошман булып берәүнең дә мантыганы юк.* Р. Төхфәтуллин. || Яхшы сыйфатлы булып үрчеп китү, төс бирү. *Мәләкәстән кайткан бу асыл сөяк сыерның нәселе, ни хикмәттер, безнең Яушырмәдә мантый алмый, икенче, өченче буыннан ук акрынлап ваклана башлый.* Э. Еники.

МАНТЫЙК *и. иск. кит.* 1. Логика. *Унбиш яшьтә мантыйк укып алдык дәрес.* М. Гафури.

2. Схоластика. *Ул күптән мәдрәсәләрнең мантыйк оясы булуыннан зарлана.* Ф. Әмирхан.

МАНТЫЙКЫЙ *с. иск. к.* логикалы. [*„Яшь гомер" әсәренең геройлары*] *вакыты белән мантыйкый үткер сүзләр әйткәлиләр.* Г. Нигъмәти.

МАНТЫЙКЧЫ *и. иск. к.* логик I.

МАНУ *ф.* 1. Берәр нәрсәне сыеклыкка яки таралучан, сибелүчән әйбергә тидереп яки батырып алу. *Майга ману. Суга ману. Каләмне карага ману.* □ *Мирхәйдәр абзый өстәлдә турап куйган суганның бер кисәген тозга манып алды да Габдуллага тоттырды.* Э. Фәйзи. || Юешләү, чылату. *Күкрәгендә ташкан куанычы Яшькә манды озын керфеген.* М. Җәлил.

2. Буяу; әйбергә берәр төрле төс бирү өчен аңа буяу сендерү. *Алъяпкыч мандым көрәнгә, Көрән матур кергәнгә.* Җыр. [*Камалның*] *бүген генә кынага манылган җирән сакалыннан - - - бер тотам төкләр йолкынды.* К. Нәҗми. || *к.* йөгертү II (1 мәгъ.). *Заһид беләгендәге алтынга манган сәгатькә карады.* А. Расих.

3. *күч. шигъ.* Нинди дә булса төскә кертү, шул төс белән каплап алу. *Куе болыт арасыннан ай чыгып бодайларны алтынга манды.* Г. Гобәй. *Галәмне алсуга манып, кояш чыкты.* И. Туктар.

4. *күч. сөйл.* Бик каты сугу; кундыру. *Чак кына манган иде бер гөрзисен, Бер песидәй тынды калды Иблисең.* Ш. Бабич. *Аның саен абзый атка берне мана, Күк айгыр да бар хәл белән алга бара.* Ак юл.

МАНУЛ *и. зоол.* Мәчеләр семьялыгыннан куе озын һәм йомшак йонлы имезүче ерткыч хайван; дала мәчесе (Закавказьеда, Урта һәм Үзәк Азия далаларында яши).

МАНУСКРИПТ *и. кит.* Борынгы кулъязма.

МАНУФАКТУР 1. *с.* Мануфактурага (1 мәгъ.) нигезләнгән. *Мануфактур хезмәт бүленеше. Капитализмның мануфактур чоры.*

2. *и. сөйл. к.* мануфактура (3 мәгъ.). — *Шәһәр базарларында ак күмәч, ит, шикәр, май, мануфактур тулып ята дигән булалар, чынмы икән?* К. Тинчурин.

МАНУФАКТУ'РА *и.* 1. Эре машина индустриясенә кадәрге хезмәт бүленешенә һәм һөнәрчелек техникасына нигезләнгән капиталистик җитештерү формасы. *Гади кооперация белән чагыштырганда мануфактураның өстенлекләре хезмәт бүленешеннән гыйбарәт.* Политэкономия. || *с. мәгъ.* Шундый җитештерү формасына нигезләнгән. *Капитализмның мануфактура чоры.*

2. Нигездә тукымалар җитештерә торган фабрика.

3. Тукыма әйберләр, кызыл мал.— *Затлырак әйберләрне мануфактурага алмаштырырга мөмкин.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Шундый тукыма әйберләр җитештерүгә яки шундый тукыма әйберләр белән сәүдә итүгә бәйләнеше булган. *Мануфактура фабрикасы.* □ *— Әти үлгәннән бирле абыйга - - - мануфактура магазиныбызны да кararга туры килә.* Ф. Әмирхан.

МАНУФАКТУ'РАЧЫ *и.* 1. Мануфактура (2 мәгъ.) хуҗасы.

2. Мануфактура (3 мәгъ.) белән сәүдә итүче. *Мин мануфактурачы Насретдин Тинишевларда приказчик булып эшли идем.* Каз. утл.

МАНЧЕ'СТЕР *и.* Киҗе-мамык тукыманың бер төре. *Менә безнең Хезмәт артистлары, Күлмәк — кызыл, Чалбар — манчестер.* М. Крыймов. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Манчестер бишмәт.* □ [*Фәхрелисламның карчыгы*] *туй бүлгә итеп Халикъка кура җилгә төсендә бик әйбәт утыз тиенлек манчестер кәләпүш - - - алып бирде.* Ш. Камал.

МАНЧУ *ф.* 1. *к.* ману 1. *Госман сөлгене суга манчып алды да [әнисенең] маңгаена куйды.* А. Шамов. *Рөстәмчек - - - чиле-пешле күкәйнең сарысына бармагын манчый-манчый ашъяулыкка рәсем ясый.* Ш. Хөсәенов.

2. *күч. шигъ. к.* ману 3. *Диңгез шадраларын нурга манчып, Кояш чыкты, балкып, зураеп.* М. Җәлил. *Тулган ай үзенең сихри нурлары белән ак кар каплаган ишек алдын, түбәләрне зәңгәрсу яктылыкка манчыган иде.* А. Расих.

МАНЧЫЛУ *ф.* 1. *Кайт. юн. к.* манчу. *Тал бөгелеп суга манчыла, Яфраклардан тама тамчылар.* Ф. Кәрим.

2. *Төш. юн. к.* манчу. *Кызыл буяуга манчылган. Көмешкә манчылган.* □ *— Фу, черкиләрегез нинди усал... Шулкадәр рәхимсез тешлиләр, — дип, одеколонга манчылган яулыгы белән маңгаена кунган чәркине куып җибәрде.* Ф. Әмирхан.

3. Буялу, пычрану, бату (канга, тузанга һ. б. ш.). *Мин идән уртасында канга манчылып хәрәкәтсез яткан Гаяз өстенә капландым.* М. Әмир. *Өс-баш сап-сары тузанга манчылды.* М. Гафури.

МАНЬЧЖУР *и.* Дунбэйдә — Кытай Халык Республикасы административ-хуҗалык районында яшәүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. || *с. мәгъ.* Шул халыкка мөнәсәбәтле. *Маньчжур теле.*

МАНЬЯК *и.* 1. Маниягә (1 мәгъ.) бирелгән кеше.

2. *күч.* Бер фикер яки идея, максат белән гадәттән тыш, үзен-үзе белештермичә мавыгучы кеше. *Атом маньяклары.* □ *— Шушылармыни инде маньяк Гитлерның соңгы терәкләре.* С. Шакир.

МАНЬЯКЛЫК *и.* Маниягә (1 мәгъ.) бирелгәнлек авыруы.

МАНЬЯ'КЧА *с.* Маньякка хас. *Маньякча караш.*

МАРАБУ *и. зоол.* 1. Ләкләкләр семьялыгыннан Африкада, Көньяк Азиядә һәм Зонд атауларында яши торган йомшак, купшы каурыйлы зур кош. *Яр буенда марабу кошлары йөри. Алар ятьмәдән алып ташланган балыкларны бик оста чукып алалар.* Соц. Тат.

2. Шул кошның бизәк өчен кулланыла торган каурые.

МАРАЗМ *и. кит.* 1. Картлык яки туктаусыз авыру сәбәпле кешенең психик һәм физик эшчәнлегендә туган тулы төшенкелек хәле.

2. *күч.* Таркалыш, артка китеш; җимерелү. *Буржуаз маразм.*

МАРАЛ *и. зоол.* Зур тармак мөгезле эре болан, Себердә һәм Урта Азиядә яши. *Озак та үтмәде, урман авызыннан искиткеч зур бер марал атылып килеп чыкты.* М. Госманов.

МАРАФОН: марафон йөгереше *спорт.* — 42 *км* 195 *м* ераклыкка йөгерү ярышы (җиңел атлетика ярышларының бер төре).

МАРАФОНЧЫ *и. спорт.* Ерак арага йөгерә яки йөзә торган спортчы. *Марафончылар ярышы.*

МАРГАНЕЦ *и.* Химик элемент, әкрен эри торган, уалучан көмеш сыман ак металл. *Пароход үзенең трюмнарына --- ун мең тоннадан артык марганец концентраты алды.* Р. Мостафин.

МАРГАНЕЦЛЫ *с.* Составында марганец булган. *Марганецлы ашламалар. Марганецлы руда.*

МАРГАНЦОВКА *и. сөйл.* Марганец сульфаты кристаллары яки эремәсе (медицинада кулланыла). *Чәчен алып бетергәч, Дамирның башын марганцовка белән юарга туры килде.* Э. Касыймов.

МАРГАРИН *и.* Туң май, үсемлек мае һәм тагы кайбер башка матдәләр катнашмасыннан хәзерләнгән ашамлык май. || *с. мәгъ.* Маргарин җитештерә торган, маргаринга бәйләнешле. *Маргарин заводы.*

МАРГАРИТКА *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан вак алсу, ак, кызыл чәчәк ата торган күпьеллык декоратив үлән үсемлек. [*Газондагы*] *назлы бегония һәм маргаритка лар Заһидны сәламләп каршыладылар.* А. Расих.

МАРЕНА *и. бот.* Тамырыннан кызыл буяу алына торган сары чәчәкле үлән үсемлек.

МАРЕНГО *и.* Ак аркау җепле кара тукыма.

МАРЕОГРАФ *и. махс.* Ачык диңгездә һәм яр буе станциясендә су тирәнлегенең үзгәрешен автомат рәвештә язып бара торган прибор.

МАРИ *и.* Угро-фин телләре группасыннан Мари АССРда яшәүче төп халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Бер богауда элек булып килгән Рус, татарлар, чуаш, марилар Бер-берсенә якын иптәш итеп, Туган итеп сөеп карыйлар.* Э. Исхак. *Бу зират дигәннәре мариларның гыйбадәт кылу урыны яисә каберлекләре булгандыр.* М. Галәү. || *с. мәгъ.* Мари халкына караган, шул халыкка мөнәсәбәтле. *Мари теле.* □ [*Ключарев*] *татар, мари, казах, башкорт көйләре өстендә эшли.* М. Җәлил.

МАРИНАД *и.* 1. Ашка тәм кертү өчен серкә һәм тәмләткечләр катнаштырып хәзерләнгән сыекча.

2. Маринадланган ашамлык.

МАРИНАДЛАУ *ф.* Җимеш, яшелчә, балык кебек нәрсәләрне маринад салып консервлау. [*Каен гөмбәләрен*], *маринадлап, кышлыкка хәзерләп куя аласың.* Г. Хәсәнов.

МАРИНАДЛЫ *с.* Маринадланган, маринад салып әзерләнгән. *Маринадлы кыяр. Маринадлы помидор.*

МАРИОНЕТКА *и.* 1. Курчак театрында: курчакчы-артист ярдәмендә уйный-хәрәкәтләнә торган курчак.

2. *күч.* Башкаларның теләге, кушуы буенча сукырларча эш итә торган кеше, дәүләт һ. б. ш. *Башка державаның марионеткасына әйләну.*

МАРИОНЕТИК *с.* Башкаларның кушуы, теләге буенча сукырларча эш итә торган. *Марионетик хөкүмәт.*

МАРИЧА *рәв.* Мари телендә. *Марича сөйләшү.*

МАРКА I *и.* 1. Нинди дә булса сурәт төшерелгән һәм бәясе күрсәтелгән, гадәттә дүртпочмаклы кәгазь формасындагы почта һәм башка төрле җыемнарны түләү билгесе. *Почта маркасы. Профсоюз маркасы.* □ *Разия* [*Рәхимгә*] *маркасыз конверт тоттырды.* А. Расих.

2. Әйбердә, товарда аның кайда эшләнгәнлеген, сыйфатын һ. б. күрсәткән билге, келәймә. *Байгилдиев, --- коньякның маркасын карап, үзенә тагын бер рюмка салды.* К. Тинчурин. || Әйбернең, товарның төре, сорты. *Заводны яңа маркадагы станоклар белән җиһазлау.* □ *— Менә син миңа шуны әйт: фрезер станогына нинди марка корычлар кирәк?* Ф. Сәйфи-Казанлы.

3. *күч.* Авторитет, дан.— *Безгә завод маркасының дәрәҗәсен күтәрү турында бик нык уйларга кирәк.* Г. Әпсәләмов. || *күч.* Кемнең дә булса характерына, билгеле бер эшчәнлегенә кире бәяләмә; кушамат. *„Тупас“ дигән марка кайсы вакыт калса да тик аңар сугылып, — Фәсхи аңлый: ялган нәзакәттән кадерлерәк тупас турылык.* Ш. Мөдәррис.— *Сиңа күз буяучылык маркасы ябыштырачаклар, минемчә.* С. Рафиков.

МАРКА II *и.* Германиядә, Финляндиядә акча берәмлеге.— *Мин инде, сайрар кош булып,* [*Мусаның*] *авызына керердәй торам, аны сыйлар өчен күпме маркалар исраф иттем.* Ш. Маннур.

МАРКА III *и. тар.* 1. Урта гасырларда кайбер Көнбатыш Европа илләрендә крестьян общиналары.

2. Элгәре феодал Франк дәүләтендә (VIII—IX йөзләрдә) һәм урта гасырда Германиядә хәрби идарәле чик буе өлкәсе.

МАРКАЛАУ *ф.* Әйбергә, товарга марка I (2 мәгъ.) ябыштыру, кую.

МАРКАЛАШТЫРУ *ф. к.* маркалау.

МАРКАЛЫ *с.* 1. Марка I (1, 2 мәгъ.) ябыштырылган, сугылган, маркасы булган. *Маркалы конверт.* □ *Низамый, өстәл өстендә яткан „Сафо“ маркалы саргылт тартманы ачып, безгә папирос тәкъдим итте.* М. Әмир.

2. Югары сортлы. *Маркалы корыч.*

Маркалы аракы — аракы җитештерүче кайбер районнарга хас һәм үзенең сыйфатын һәрвакыт үзгәрешсез саклый торган виноград аракысы.

МАРКЁР *и. махс.* Берәр нәрсә утыртканда яки чәчкәндә буразна ясау яки сызык сызу өчен агрегатка беркетелгән җайланма. [*Кукуруз*] *утыртылган участокның кайсы ягына гына карама, тигез квадратлар аермачык беленә: маркёр сызыкларын трактор белән үткәрделәр шул.* Э. Касыймов.

МАРКИЗ *и.* Кайбер Көнбатыш Европа илләрендә граф белән герцог арасында торган дворян титулы; шул титулга ия булган кеше.

МАРКИЗА *и.* Маркиз хатыны яки кызы.

МАРКИЗЕТ *и.* Бик нечкә җептән тукылган үтә күренмәле киже-мамык яки ефәк тукыма. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Күз явын алырлык бизәкле маркизет күлмәк кигән Дилбәр Гөлнурны кояш кебек балкып каршы алды.* Г. Ахунов.

МАРКИРЛАУ *ф. махс.* Маркёр белән сызу, буразналар еру.

МАРКИРОВКА I *и.* Марка I (2 мәгъ.) сугу, келәймәләү эше.— *Озакламыйча машиналар килеп җитәргә тиеш, барлык әзер бүрәнәләргә маркировка ясап бетерергә кирәк.* Г. Әпсәләмов.

МАРКИРОВКА II *и.* Маркирлау эше.

МАРКИТАНТ *и.* XVIII—XIX йөзләрдә армиядә ашау-эчү әйберләре, әчемлекләр һ. б. ш. солдат кирәк-яраклары белән сату итүче.

МАРКИТА'НТКА *и.* Хатын-кыз маркитант. *Узенең дан йолдызына менеп баручы Фатыйма Ильскаяның бу спектакльдәге маркитантка ролен башкаруы истә калган.* Ф. Хөсни.

МАРКСИЗМ *и.* Табигать һәм җәмгыять үсеше законнары, изелүче һәм эксплуатацияләнүче массалар революциясе, барлык илләрдә социализмның җиңүе, коммунистик җәмгыять төзү турындагы фән. *Марксизм әдәбияты.* □ *Газетада татар большевигы Хөсәен Ямашев һәм революцион язучы Гафур Колахметовлар ярдәме белән марксизмның нигезләре --- турында озын-озын мәкаләләр басыла.* М. Гали.

МАРКСИЗМ-ЛЕНИНИЗМ *и.* Империализм һәм пролетар революцияләр эпохасының яңа тарихи шартларында В. И. Ленин тарафыннан алга үстерелгән Маркс һәм Энгельс тәгълиматы. *Марксизм-ленинизмны нигезләүчеләр К. Маркс, Ф. Энгельс һәм В. И. Ленин антагонизм дигән сүзне сыйнфый җәмгыять каршылыкларының характерын ачыграк күрсәтү өчен кулланалар.* М. Абдрахманов.

МАРКСИСТ *и.* Марксизм тарафдары. *Маркс һәм Энгельс әсәрләрен җентекләп өйрәнү, аларның серләренә көн саен тирәнрәк төшенә бару, рәсми газета-журналларны күзәтүләр --- [Владимир Ильичны] тирән ышанган марксист итте.* Г. Әпсәләмов.

МАРКСИ'СТИК *и.* Марксизмга һәм марксистларга хас, марксизм принципларын чагылдыра торган. *Марксистик партия.* □ *— Володя, сиңа бер кызыклы сер әйтимме? Озакламый Казанда марксистик түгәрәк оештырыла.* Р. Ишморат.

МАРКСИ'СТИК-ЛЕ'НИНЧЫЛ *с.* Марксизм-ленинизмга хас; марксизм-ленинизм принципларын чагылдыра торган. *Дөньяга марксистик-ленинчыл караш.* □ *Татар әдәби тәнкыйте дөньясына марксистик-ленинчыл эстетика идеяләре --- торган саен көчлерәк һәм тирәнрәк керә* [*бара*]. Х. Госман.

МАРКШЕ'ЙДЕР *и.* Маркшейдерия белгече. *Маркшейдерларны җир асты лоцманы дип атыйлар: аларның хисаплаулары һәм үлчәүләре нигезендә җир астындагы байлыкларга юллар салына.* Соц. Тат.

МАРКШЕЙДЕРИ'Я *и.* Тау фәне һәм техникасының геодезия һәм геология элементларын эченә алган тармагы.

МА'РЛЯ *и.* Башлыча яраларны бәйләү өчен кулланыла торган сирәк һәм юка ак киже-мамык тукыма. *Марля аша сөзү.* □ [*Фельдшер*] *Мәдинәнең бармагына йод сөртеп, марля белән урады.* Ш. Камал.

МАРМЕЛАД *и.* Җиләк-җимеш измәсенә шикәр һәм бәрәңге балы кушып әзерләнгән конфетның бер төре. [*Гөлҗимештә витамин*] *лимон һәм алмаларга караганда йөз тапкыр мулрак. Бары чи килеш, баллы килеш ашап кал. Кагын һәм мармеладын ясап кал.* Г. Хәсәнов.

МАРОДЁР *и.* Сугыш кырында яки сугыш хәрәкәтләре барган районда яралы һәм үлгән сугышчыларны талаучы кеше; сугыш вакытында халыкны талаучы мораль яктан таркалган солдат. *Солдатлар сафы каршына бастырып, аэродромда унлап дезертир һәм мародёрларны аталар.* Р. Мостафин. *Туган илгә мәхәббәтебезнең Гәүһәрләрен талый мародёр.* Х. Туфан.

МАРОДЁРЛЫК *и.* Мародёр кешегә хас гадәт, шөгыль. *Гриша яшьтән үк иске гаскәр полкында тәрбияләнгән, шунда --- патша гаскәренең начар традицияләрен, талаучылык, мародёрлыкны үзләштергән иде.* Ш. Усманов.

Мародёрлык итү — мародёрлык белән шөгыльләнү. *Үлекләрнең кесәләрен тентеп, Мародёрлык итте патша солдаты.* Бәет.

МАРОКЕН *и.* Ясалма ефәктән тыгыз итеп эшләнгән тукыма төре. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Марокен плащ.*

МАРС I *и.* 1. Борынгы Рим мифологиясендә: сугыш алласы.

2. Кояш системасындагы 9 зур планетаның берсе (Кояштан дүртенче).

МАРС II *и.* Парусларны идарә итү, горизонтны күзәтү өчен корабль мачтасында ясалган кечкенә мәйданчык.

МАРСЕЛЬЕ'ЗА *и.* Франциядә чыгарылган, соңыннан Франциянең милли гимны булып әверелгән революцион җыр.

МАРСИАН *и.* Марс планетасында яши дип уйланылган зат. *Белмим, марсианнар ничек* [*яши*] *икән?* Н. Дәүли.

МАРСЫК *и. диал.* 1. Тамырлары чуалып, бергә укмашып үскән каты агач төбе. *Марсык яна белмәс, Янса сүнә белмәс.* Мәкаль.

2. *күч.* Тискәре, кире кеше. *Урманлы якларда яшәүче күмер яндыручы татарлар тискәре, кире кешене „марсык!" дип атыйлар.* К. Нәҗми.

МАРТ *и.* Календарь елның өченче ае. *Кар белән бер вакытта бетәдер март, Апрель туса, дөнья була суга юмарт.* М. Гафури.

МАРТЕН *и.* Мартен миче. *Гүләп торган мартеннардан Ахактай корыч акты.* Г. Хуҗиев.

Мартен миче — корыч эретү, кою өчен махсус җайланмалы мич.— *Тамара, син хәзер приказ әзерлә. Беренче мартен мичен ремонтка сүтәргә.* Н. Исәнбәт.

МАРТЕНЧЫ *и.* Мартен цехы эшчесе. *Мартенчылар бригадасы. Мартенчыларны корыч коюдагы яңа уңышлары белән котлау.*

МАРТЫ'ШКА *и.* Макакалар токымыннан кечкенә маймыл.

МАРШ I *и.* 1. Сафта ритмик тигез, салмак атлап йөрүysулы. *Походка таңнан торып китәләр. Марш атлыйлар, йөгерәләр, „түш белән шуышып" йөриләр. Окоплар казыйлар.* Г. Гобәй.

2. Сугыш хәрәкәтләре планы таләп иткәнчә, гаскәрнең бер урыннан икенче урынга күчүе; поход. *Полк төн буе маршта булды.* Г. Кутуй. *Батальон кичә йөз километрлык марш үтте, маршtан кайтуга, фронтка күчте һәм төн буенча дошманны күзәтте.* И. Салахов. || *с. мәгъ.* Запастагы гаскәрләрдән хәрәкәттәге армиягә аны тулыландыру өчен жибәрелә торган. *Марш роталары.* □ *Дошман сугышларда сирәгәйгән дивизияләрен тулыландырып торды, йөзләрчә танклар, бронетранспортерларга утырган марш батальоннары белән көчәйтте.* Каз. утл.

3. Сафта атлап бару тактына корылган бер үлчәүле, ритмлы музыкаль әсәр. *Ераста оркестр гаскәри марш уйный.* Ш. Камал. *Поход маршларын җырлый-җырлый, Махноларга каршы кузгалдык.* М. Җәлил.

МАРШ II *ы.* 1. Сафта торучыларга кузгалып китәргә команда биргәндә кулланыла торган сүз. *Командирның көчле, нечкә тавышлы командасы ишетелде. — Марш кире!* Ш. Усманов. *Канлы һәм изге, гадел сугышка Марш, марш, алга, эшче халык!* Җыр.

2. Кая да булса китәргә, керергә яки чыгарга катгый боеру.— *Хәзер үк палаталарыгызга кереп китегез! — диде ул яралы кызылармеецларга.— Хәзер үк! Марш!* А. Шамов.— *Марш моннан, уңайсызлап йөрмә син безгә.* Н. Баян.

МА'РШАЛ *и.* 1. Югары команда составындагы аеруча зур хезмәт күрсәткән кешеләргә СССР Верховный Советы Президиумы тарафыннан бирелә торган хәрби звание; шундый дәрәҗәдәге кеше. *Авиация маршалы. Советлар Союзы Маршалы.*

2. Кайбер дәүләтләрнең армияләрендә иң югары хәрби дәрәҗә, чин; шундый дәрәҗәдәге кеше.

МАРШАЛЛЫК *и.* Маршал дәрәҗәсе, чины. *Маршаллыкка күтәрү.*

МАРШИРОВКА *и.* Марш I (1 мәгъ.) белән йөрү. [*Офицерлар*] *маршировкаларга, солдаттан титуллар ятлатуга да ул чаклы каныгып ятмыйлар.* Ф. Хөсни.

МАРШРУТ *и.* Төп юнәлеше һәм үтеләчәк пунктлары алдан ук билгеләнеп куелган юл. *Безнең [туристларның] маршрут баштан алып соңынача менә шулай булырга тиеш иде: Мәскәү — Варшава — Берлин — Париж.* Г. Гали. *Майор миңа боерыгын бирүгә, мин картадан шул авылны әзли башладым, төрле юллар белән аны үземнең маршрутыма кертергә тырыштым.* А. Расих.

МАРШРУТЛЫ: маршрутлы поезд — билгеләнгән урынга хәтле үзенең составы һәм йөге үзгәртелмичә бара торган товар поезды.

МАРҖА *и. сөйл.* Рус хатын-кызы.— *Гыйззәтулла абзыйлар да Хәсбикамалны укытырга маржа яллаганнар икән дә, бик күпшы маржа булган ди.* Ф. Әмирхан. *Биредә --- вагын-төяген, сөтен-маен сатучы маржалар җыела.* Г. Минский.

Маржа башмагы *бот.* — икеөлешлеләр семьялыгыннан сары яки шәмәхә һ. б. ш. чәчәкле берьеллык һәм күпьеллык чүп үләне яки декоратив үлән үсемлек; *русчасы:* льнянка. *Дә маржа башмагы чәчәгенә төклетура кереп чумган.* И. Гази. **Маржа башы** *диал.* — киптерү өчен, башакларын югары каратып, бер-берсенә сөяп утыртылган һәм өстән бер көлтә белән ябылган 6—10 көлтә өеме. *Кырда җир буенча рәт-рәт тезелеп куелган маржа башлары шактый күбәйгәннәр иде.* Ф. Әсгать.

МАСАЕШУ *ф. к.* масаю. *Икесе дә борын чөялар, мактаналар, әтиләренә таянып масаешалар: бай кызлары бит.* Каз. утл.

МАСАЙТУ *ф.* Масаерга (1 мәгъ.) мөмкинчелек бирү, узындыру. *Сөләйман старостаның олы хатыны Хәрниса: „Менә безнең авылда да балалары кызылларга ияреп киткән кешеләр бар. Аларны монда масайтып йөртмәсләр әле",— дип әйтә ди.* М. Гафури.

МАСАЮ *ф.* Үзен башкалардан өстен күрсәтергә тырышу, әреләнү, һавалану; мактану. *Байлык белән масаю. Көч белән масаю.* □ *— Гафур җизни соңгы вакытта бик масайган иде масаюын. Колхозчыларны санга санамый башлаган иде.* Р. Ишморат. *Хәзер инде Шәрифулла үзенең осталыгы белән масаймый, ә хаклы рәвештә горурлана гына.* А. Шамов. || Горурлану. *Яшәгез, кызлар, Бар масаерга Сезнең хакыгыз. Күпме батырлар Алып кайтты илгә Сезнең хатыгыз.* М. Җәлил.

МАСАЮЧАН *с.* Мактанчык, тәкәббер, әреләнүчән, һавалы.

МАСАЮЧАНЛЫК *и.* Масаючан кешегә хас сыйфатлар.

МАСДАР *и. иск. лингв.* Исем фигыль. *„Сулланмак" шикелле сүзләргә гарәпчә масдарлар табып булмый иде әле.* Г. Тукай.

МАСКА *и.* 1. Биткә кию өчен кеше йөзе яки хайван башы формасында эшләнгән махсус япма. *Төлке маскасы. Аю маскасы. Маскалар театры.* □ *Артистлар һәм композиторларның биредә Маскалары тора.* С. Хәким. *Янадыр ла безнең йөрәк, Беләсезме безгә ни кирәк? Артисткалар һәм маскалар, Көн дә театр һәм цирк.* Ш. Мөхәммәдев. || Кеше танымасын өчен күз тирәләрен каплап кия торган япма, бәйләвеч (күзләр өчен кечкенә тишекләр уеп алынган була).

2. *махс.* Битне саклау өчен киелә торган япма; битлек. *Противогаз маскасы. Фехтование маскасы.*

3. Кеше йөзенең яки хайван башының скульптур сурәте. || Гадәттә үлгән кеше йөзеннән алына торган гипс күчермә.

4. *күч.* Кемнең яки нәрсәнең дә булса чын асылын яшерә торган ясалма тышкы күренеш, кыланыш, эшчәнлек.— *Безнең бу тирәдә милләтчеләр, эсерлар күп һәм көчеләр, атлаган саен „изелгән милләт маскасы" астында революция үсешенә аяк чалалар.* Т. Гыйззәт.— *Мин бөтен яшь гомеремне маска эчендә уздырырга разый була алмыйм.* Ф. Әмирхан.

5. Хәрби маскировка өчен җайланма.

◇ **Маска кию** — берәр максат белән үзеңнең кемлегеңне яшерү, икейөзлеләнү. **Масканы салу** — үзеңнең кемлегеңне яшерүдән, икейөзлеләнүдән туктау. *Әле контрреволюция битендәге масканы салмаган чакта, алар станицаның большевиклары булып хисапланалар, үз тирәләренә ярлы казакларны җыйганнар иде.* Ш. Усманов.

МАСКАРАД *и,* 1. Маска һәм махсус (әкияткә хас яки этнографик һ. б. ш.) костюмнар кигән кешеләр катнашында үткәрелә торган кичә, бал. *Көн дә театр, көн дә цирк, калмады бездән маскарад.* Ш. Мөхәммәдев. || *с. мәгъ.* Шундый кичәдә, балда кия торган. *Маскарад костюмы.*

2. *күч.* Ясалмалык, ялган кыланыш.

МАСКИРОВКА *и.* 1. Маскировкалау эше. *Шәһәрдә һаман маскировка дәвам иткәнлектән, беркайда да ут күренми.* М. Әмир.

2. Маскировкалау өчен куелган яки кулланылган нәрсә. *Тәрәзәләрдә маскировка булганлыктан, өй эче дөм караңгы.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Маскировкалау өчен билгеләнгән. *Әлфия, тәрәзәләргә маскировка бөркәвечләре элеп, өстәл хәзерли башлады.* Г. Бәширов.

МАСКИРОВКАЛАУ *ф.* Күренмәслек, сизелмәслек итеп ябу, каплау. *Капитанның кушуы буенча [пароходны] шунда ук яшел куаклар белән маскировкаладылар.* Х. Садрый. *Немецлар үз позицияләрен бик яхшылап маскировкалаганнар.* Каз. утл.

МАСКХАЛАТ *и. хәрби.* Маскировка (1 мәгъ.) өчен кия торган махсус халат. *Лейтенант белән икесе, маскировка складына барып, язгы табигать үз канаты астына яшерә ала торган төстәге маскхалатлар киеп юлга чыктылар.* Ф. Кәрим. *Сугышчының маскхалаты салкынга эленгән юеш кер кебек каткан.* Г. Әпсәләмов.

МАСЛЁНКА *и.* Машиналарны майлау өчен эшләнгән махсус савыт. *Ашыга-ашыга машинаның маслёнкаларына май тутыра башладым.* Х. Садрый.

МАСОН *и.* Масонлык тарафдары.

МАСОНЛЫК *и.* XVIII йөздә Англиядә барлыкка килеп, аннан яшерен оешмалар рәвешендә башка илләргә дә таралган, „эхлакый камилләшү" бурычларын политикада реакцион карашлар белән бәйли торган дини-философик агым.

МАССА I. *и.* 1. Җисемдәге матдәнең микъдарын билгели торган зурлык; җисемнәр инерциясен һәм аларның гравитацион үзенчәлекләрен үлчәү берәмлеге. *Җисемдәге матдә никадәр зур булса, аның массасы да шулкадәр зур була.* Физика.

2. Нәрсәнең дә булса микъдары, күләме. *Су массасы.*

3. Камыр сыман, формасыз матдә; нәрсәләрнең дә булса куе яки ярым сыек катнашмасы. *Утлы масса. Магма массасы. Бал сыман сыек масса.*

МАССА II *и.* Киң катлау хезмәт ияләре, халык; бик күп кешеләрне әченә алган төркем. *Ленни Маркс әсәрләрен акка күчергән, аларны массага таратырга*

булышкан. Г. Кутуй. *Тәнкыйтьтән өстен ˌСаный ул үзен: Искә дә ˌалмый Массаның ˌсүзен.* Х. Туфан. || Үзләренә хас аерым билгеләр белән характерлана торган кешеләр коллективы турында. *Студентлар массасы. Шахтерлар массасы.* □ — *„Бетсен сугыш, бөтен власть Советларга!" дигән лозунглар белән эшче-солдат массалары урамнарга чыктылар.* Т. Гыйззәт.

МАССАЖ *и.* Дәвалау яки косметик максат белән тәнне күл белән ышку, уу, сылау. *Көнчыгыш [халкы] --- борын-борыннан массаж белән шөгыльләнә[гән]. Безнең татар карчыклары да элек-электән арка сылатырга яратканнар.* Г. Әпсәләмов.

МАССАЖЛАУ *ф.* Массаж ясау, сылау.

МАССАЖЧЫ *и.* Массаж ясаучы, массаж ясау белгече. *Футбол командасы массажчысы.*

МА'ССА-КҮЛӘМ *с.* 1. Киң масса, бик күп кешеләр катнаша торган. *Митинглар, демонстрацияләр, стачкалар масса-күләм төс алалар.* Яңа тарих. || Киң күләмдә була, башкарыла торган. *Масса-күләм агарту эшләре.* □ *Капиталистлар әледән-әле масса-күләм эшсезлекне хезмәттәге эшчеләрнең эш хакын киметү өчен файдаланалар.* Политэкономия.

2. Киң катлау кешеләр, массалар өчен билгеләнгән. *Масса-күләм товарлар.*

3. Күп итеп эшләнә торган. *Масса-күләм җитештерү.*

МА'ССАЛАШУ *ф.* Массага (II) таралу, халык тарафыннан үзләштерелү. *Ясалган сүзләрнең барлыгы да телнең сүзлек составына урнашып китми; күп яңа сүзләр авторлары теләндә генә чагылып кала, массалашмый.* Ш. Рамазанов.

МА'ССАЧЫЛ *с.* Киң масса, бик күп кешеләр катнаша торган. *Әдәби әсәрдә массачыл күренешләрне оста сурәтләү.*

МАССИВ I *и.* 1. Геологик төзелеше ягыннан бердәй булган яссы түбәле тау калкулыгы. *Альп таулары массивы.*

2. Берәр географик билгеләре буенча бер төрле булган зур урын, пространство. *Әреле-ваклы күллар, урман массивлары, иген басулары, авыллар очрый.* Каз. утл.

МАССИВ II *с.* Авыр, зур күләмле. *Искәндәр --- телеграмманы пафоссыз гына укып чыкты да, икегә бөкләп, массив кара савыт белән бастырып куйды.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

МАССО'ВКА *и.* 1. Октябрь революциясенә кадәрге Россиядә: яшерен җыелыш, зур булмаган митинг. *Булатлар кырыкка ярылалар. Митингтан түгәрәккә, түгәрәктән заводка, аннан массовкага чабалар.* Г. Ибраһимов.

2. Күңел ачу, ял итү өчен күп кешеләр катнашында оештырылган экскурсия.

МА'СТЕР *и.* 1. *сөйл.* Нинди дә булса һөнәр белән шөгыльләнүче квалификацияле эшче, нинди дә булса һөнәр остасы. *Төзелештә „Красногвардеец"ның үз балта осталары белән бергә күрше рус, чуваш колхозларыннан килгән мастерлар да эшли иде.* Г. Әпсәләмов.—*Эшкә өйрәнеп, инде үзең чын-чын мастер булып киткәч, [эш хакың] йөзгә дә, артыкка да менәр.* Ф. Әмирхан.

2. Аерым бер эш участогының (цехның, сменаның һ. б.) административ, техник җитәкчесе.—*Итек мастерскоенда мастер булып эшлим, — диде ул үзе турында.* А. Шамов. *Алафузовчылар эш ташлаганнар: эш хакын арттыруны, ике мастерны эштән чыгаруны, эш вакытын киметүне сорыйлар.* И. Гази.

3. Танылган спортчыларга, шахматчыларга бирелә торган исем; шул исемгә ия булган кеше. *Танылган спорт мастеры. Шахмат мастерлары турниры.*

МА'СТЕРЛАРЧА *рәв.* Мастерларга хас булганча; үрнәк булырлык итеп, зур осталык белән. *„Банкрот" — Г. Камалның мастерларча язылган һәм сюжетлы комедияләреннән берсе.* М. Гали.

МА'СТЕРЛЫК *и.* 1. Мастер (1 мәгъ.) булу дәрәҗәсе, мастер вазифасы.— *Мин бит бирегә [Лена нефть промыселына] килгәч мастерлыкка имтихан тоттым.* Ә. Маликов.

2. Югары сәнгатьлелек; берәр эшкә зур осталык. *Опера өзекләре өстендә вокаль эшләү бер үк вакытта актерлык мастерлыгын үзләштерү белән бергә алып барылды.* М. Җәлил. || *сөйл. ирон.* Берәр нәрсәгә һәвәслек; нәрсә белән дә булса артык мавыгучанлык. — *Синең, Гали кордаш, ул якка да [әчәргә дә] мастерлыгың барын яхшы беләм.* А. Әхмәт.

МАСТЕРОВОЙ *и.* Даими рәвештә нинди дә булса бер һөнәр белән шөгыльләнүче һәм ялланып эшләүче кеше; завод-фабрика эшчесе. *Сабын кайнатучы мастеровойлар.* □ *Шәһәр кырыйларында татарлар тора торган урамнарга барып карагыз: анда көне буе эшләп тә эшләгән әйберләренең бәһасе юклыктан зар елаган ярым ач мастеровойларны күрерсез.* Ф. Әмирхан.

МАСТЕРОК *и.* Измәне кирпеч араларына яки бетон, кирпеч стенага сылау өчен кулланыла торган махсус калак. *Кичке караңгыга кадәр бу куллардан мастерок белән измә чиләге төшми иде.* Р. Төхфәтуллин. *Япь-яшь кешеләр кирпечләрне тигез, пөхтә түшиләр, мастероклар, оста кулларга буйсынып, күндәм йөриләр.* С. Рафиков.

МАСТЕРСКОЙ *и.* 1. Нинди дә булса әйберләр ремонтлау яки эшләп чыгару белән шөгыльләнә торган зур булмаган предприятие; шул предприятие урнашкан бина яки бүлмә. *Ремонт мастерское. Тегү мастерское. Агач эшләре мастерское. Тимер юл мастерское.* □ *Тыкрыкка сыенып утырган кечкенә мастерскойда картлар тырма һәм арба кебекләрне төзәтеп маташалар.* Г. Бәширов.

2. Цехның, завод яки фабриканың бер бүлеге. *Казнага кием-салым тектерүче фабрикант Шабанов, эшчеләрнең таләпләренә җавап итеп, өч мастерскоен япкан, ике мең эшчене урамга куып чыгарган.* И. Гази.

3. Рәссам, скульптор, архитекторлар эшли торган бүлмә. *Скульптор мастерское.* □ *Мастерской'житәкчесе Шәехзадин өчен бар дөнья архитектура белән чикләнгән иде.* М. Маликова.

МАСТИ'КА *и.* 1. Ябыштыру һәм вак скульптура әйберләре ясау өчен кулланыла торган сумалалы һәм майлы куе масса.— [*Чертежга тамган караны*] *мастика белән, өстенә кәгазь ябыштырыпмы --- бетерергә кирәк.* Н. Исәнбәт.

2. Паркет идәннәрне ышкып ялтырату өчен балавыз һәм буяу катнашмасыннан торган сыекча. *Балавыз --- паркет идәннәрне ялтырату өчен, мастика, итек кремы һәм башка шундый әйберләр хәзерләү өчен киң рәвештә кулланыла.* Умартачылык.

3. Кайбер агачларның хуш исле сумаласы.

Мастика агачы — Урта диңгез буенда үсә һәм хуш исле сумала бирә торган мәңге яшел агач үсемлек. *Ямәндә --- хуш исле сәрви агачы, мирра, мастика агачы, банан, хөрмә һәм цитрус агачлары үсәләр.* Сов. әд.

МАСТОДОНТ *и.* Гәүдә төзелеше белән филгә охшашлы, казылмаларда табыла торган бик эре хайван. *Моннан берәр миллион еллар чамасы элегрәк Кара диңгез буйларында, Көнбатыш Себердә страус, газель, дөя, жираф, носорог, мастодонт һәм башка шундый төрле хайваннар яшәгән.* Җир һәм туфрак.

МАСТЬ *и.* Уен карталары колодасында тамгаларының формасы һәм төсе буенча төркемләнгән дүрт төрнең берсе. *Буби масте. Черви масте.*

МАСШТАБ *и.* **1.** Картада, сызымда һ. б. ш. шартлы рәвештә алынган озынлыкның, зурлыкның чынбарлыктагы озынлыкка, зурлыкка мөнәсәбәте. *Ераклыкны картаның масштабы буенча билгелә́у.*

2. *күч.* Күләм, колач (2 мәгъ.). *Фәннең практик кулланыш масштаблары киңәю.* □ *Яйсан җиңүе, зур масштаб белән үлчәгәндә, безнең фронт өчен алдагы җиңүләрнең беренче карлыгачы иде.* Ш. Усманов.

МАСШТАБЛЫ *с.* **1.** Масштабы булган, масштабы күрсәтелгән. *Масштаблы линейка.*

2. *күч.* Зур күләмле, киң колачлы. *Масштаблы проблемалар өстендә эшлә́ү.* □ *Әсәрдә үзәк образ никадәр колачлы һәм масштаблы булса, аңа шулкадәр күбрәк „йөк" салып була.* Каз утл.

МАСШТАБЛЫЛЫК *и.* Зурлык, зур күләмлелек, киң колачлылык. *Кожанов --- масштаблылыкка, ил күләмендәге данга дәгъва кылды. Тик аның колач киңлеге үз мәнфәгатенә, карьерачылыкка нигезләнгән булып чыкты.* Г. Ахунов.

МАТ I *и.* Шахмат уенында корольнең каршы як фигураларының атакасыннан саклана алмау хәле, оттырыш. *Мат алу. Мат бирү.* □ *Шаһвәлиев аңа дүрт йөрүдә мат куйды.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Бик кыен, читен хәл.

◇ **Мат булу** — *иск.* үлү. *Тай ат булганчы — иясе мат була.* Мәкаль. **Мат итү** — *диал.* аптырату, йөдәтү, җәфалау. *Картлык, сине кая итим, әйтер сүзгә мат иттең.* Мәкаль.

МАТ II: **чат та мат килү** — бик кызу һәм туктаусыз оста сөйләп тору.

МА!ТА I *и. иск.* Мамык тукыма. *Ата даны белән кыз үтәр, Мата даны белән бүз үтәр.* Мәкаль.

МА!ТА II, **МА!ТЫ** *и.* **1.** Саламнан, камыштан, берәр төрле тупас яки калдык-постык материалдан үреп ясалган җәймә, чыпта.— *Салам маталарны әзерләгәннәрме, китергәннәрме? Суытып җибәрсә, бетонны сакларга кирәк булачак.* А. Гыйләҗев. *Хәзер без аңардан [баудан] аяк сөртеп керү өчен ишек катына җәя торган матылар тегәбез.* Г. Гобәй.

2. Төрле спорт күнегүләрендә спортчыны егылган яки сикергән вакытларда бәрелеп имгәнүдән саклау өчен йомшак калын җәймә.

МАТАВЫК *и. диал.* **1.** Мәшәкать, комачау; һәртөрле борчулар. *Безнең йөрәкләрдәге сезгә булган мәхәббәт һәрвакыт ялкын кебек кайнар, беренче күз яшебез кебек саф. --- Тик без аны бүгенге һәм иртәгәге эшләр матавыгында, килачәккә ашкыну кызуында сезгә белдерә генә алмыйбыз.* Ш. Хөсәенов. || Ыгы-зыгы, шау-шу, буталыш. *Баязитов аптырашып торган егетләренә: „Бу матавыктан чыгызыз, атлар катына барыгыз!" — дип ишарәләде.* И. Гази. *Котлары очкан пассажирлар, палубага чыгып, зур матавык кузгаттылар.* С. Сабиров.

МАТАВЫКЛАНУ *ф. диал.* Берәр төрле эш белән мәшгуль булу. *Балыкка барырга хәзерләну белән матавыкланып йөрү.*

МАТАВЫКЛАУ *ф. диал.* Комачаулау, мәшәкать ясау. *Аю балалары аш өендә эшләүчеләргә матавыклап йөдәтеп бетерәләр иде.* Ак юл.

МАТАВЫКЛЫ *с. диал.* Мәшәкатьле, борчулы, тынгысыз.— *Миңһаҗ абзый, безнең эш бик матавыклы бит, күп йөгерергә туры килә.* А. Расих.

МАТАДОР *и.* Үгезләр белән көрәштә (Испаниядә) төп сугышучы, үгезгә шпага кадаучы; тореадор.

МАТАЛАНУ *ф. диал.* **1.** Маташу, мәшәкатьләнү. *Бу азапланулар файдасыз маталану гына булып калдылар.* Тат. театры.

2. *күч.* Ялагайлану, яхшы булып күренергә, ярарга тырышу. *Бераздан әткәй килде, хәлемне карап белде. Әткәйгә, маталанып, бай абзый бүләк бирде.* Бәетләр.

МАТАУ *ф. диал.* Комачаулау, уңайсызлау.— *Кеше монда, җан тиргә батып, яңа чыккан көйне өйрәнергә тырыша, ә син аңа матыйсың.* Т. Гыйззәт.

МАТАШТЫРУ *ф. сөйл.* **1.** Нәрсә дә булса эшләргә тырышу, омтылу. [*Ясәви:*] *Тукта әле, минем кесәдә ачкычлар бар бугай, бәлки берәрсе ярый торгандыр.* [*Зәмзәмбану:*] *Чыннан да, маташтырып кара әле, ача алмассыңмы?* Т. Гыйззәт.

2. Күп кенә фигыльләр урынына кулланылып, алар белдергән эш-хәлнең кыенлык белән, гадәттә түбән сыйфатлы итеп башкарылуын белдерә. *Ул скрипкада маташтыра, әлегә яхшы уйный алмый.* Г. Тукай. [*Бәдри, хатны Галимәгә бирепː*] *Мә әле, син маташтыра алмассыңмы?* М. Фәйзи. [*Исмаев*] *русчаны ваткалап булса да маташтыра бит.* Г. Бәширов.

3. Бозу, казыну, нәрсә дә булса эшләтү.— [*Сәгатебез*] *бик дөрес йөри иде, — дип аптырады Камилнең әнисе, — син маташтырмагансыңдыр бит, улым?* А. Әхмәт. || *күч.* Бозу, ялгыш юлга кертү; бутау.— *Халыкны агартам дигән булып, яшьләрне маташтырып бетердең.* М. Фәйзи.

4. *күч.* Шаярту, үртәү; аптырату.— *Син моны чынлап әйтәсеңме, авылдаш, әллә маташтырган буласыңмы?* Ф. Хөсни.— *Мәйсәрә, ахирәт, сөенеч, сөенеч, сөенеч! — Я, әйт инде, Заһирә, маташтырма.* К. Тинчурин.

МАТАШУ *ф. сөйл.* **1.** Берәр эш белән мәшгуль булу; шул эш белән мавыгу, азаплану.— *Мин бит элек тә урман эшендә аз-маз маташкалаган кеше.* Г. Әпсәләмов. *Язга чыксаː тагын иген чәчә, Җәй буенча кырда маташа.* М. Гафури. || *ып-еп* формасындагы хәл фигыльләрдән соң килгәндә: эшнең акрын, кыенлык белән яки өстән-өстән генә башкарылуын, ироник мөнәсәбәтне белдерә. *Әткәй бакча буенда арба төзәтеп маташа иде.* Г. Ибраһимов. *Марат, күзләрен Сания ясап маташкан рәсемнән алып, Гөлсем апага карады.* Г. Гобәй.

2. Нәрсә дә булса эшләргә тырышу, омтылу, ниятләну, җыену. *Маташмагыз якты көнне караларга, Дошманлык салырга дип араларга.* Г. Камал. *Күрәсең, ул аңа җитәрлек каты сукмаган булса кирәк, чөнки бандит торырга маташа иде.* А. Шамов.

3. Кем яки нинди булып күренергә тырышу, кылану.— *Д син алай артык кызылланып маташма!* Һ. Такташ. [*Миңһаҗ Тимеркәйгә:*] *Төш күрәсеңме, юри маташасыңмы, әллә саташасыңмы?* К. Тинчурин.

МАТБАГА *и. иск.* Типография. *Матбага һәм нәшрият эшен алып барган Гыйльметдин Шәрәф --- баю, мал җыюга омтыла иде.* З. Бәшири.— *Иптәшләр, гафу итәсез, афишада матбага хатасы киткән.* Ш. Камал.

МАТБАГАЧЫ *и. иск.* **1.** Типография эшчесе.

2. Типография хуҗасы. *Матбагачы — матбугат эшен [бакалея] кибетенә әйләндереп файда күрүче.* Г. Тукай.

МАТБАГАЧЫЛЫК *и. иск.* Типография эше; китап бастырып чыгару эше. *Татарда матбагачылык тарихына караган беренче сүзне Р. Фәхретдинов, Ш. Әхмеров һәм И. Рәмиевләр әйтеп үттеләр.* Ә. Кәримуллин.

МАТБУГАТ *и.* **1.** Басылып чыккан әдәбият, вакытлы басмалар (газета-журналлар). *Матбугатта мактап каршы алуларга карамастан, мин китап чыгу белән*

үземдә тирән канәгатьсезлек сизендем. Г. Ибраһимов. *Матбугатыбыз хәзерге көнгә кадәр комедияләргә бик фәкыйрь.* Ф. Әмирхан.

2. Басма әдәбият чыгару эше; нәшрият һәм типография эше. *Революцион көрәш нәтиҗәсендә азмы-күпме әдәбият һәм матбугат иркенчелегенә ирешелде.* М. Гали.

МАТБУГАТЧЫ *и.* Матбугат хезмәткәре.

МАТДИ *с.* **1.** Милеккә, эш хакына, акчага бәйләнешле; *к.* материаль 3. *Матди хәл. Матди ярдәм. Матди бәйлелек.* □ [*Батырхан:*] *Хәзерге вакытта Милли идарәнең матди ягы бик начар.* К. Тинчурин. *Әхмәт әфәнденең ул әсәрләре аңа һичбер матди файда китермиләр иде.* Г. Газиз.

2. *к.* материаль 1. *Матди дөнья.*

◇ **Матди егылу** — зур мохтаҗлыкка дучар булу. *Иптәшләрем күңелсезләнергә бирмәсәләр, башкалар матди егылудан саклап калдылар.* Г. Кутуй.

МАТДИЛЕК *и.* Матди (2 мәгъ.) булу сыйфаты, хәле. *Дөньяның матдилеге.*

МАТДӘ *и.* **1.** *филос. к.* материя. *Матдә бөек үсеш аркылы Бөек затны — кешене бар кылды.* Х. Туфан.

2. Материянең сыйфат күренеше; физик җисемнәрне тәшкил иткән нәрсә (әйбер). *Органик матдәләр. Химик матдәләр.* □ *Җирнең өс кабыгы, эчендәге матдәгә караганда тыгызрак булганга күрә, акрынрак кысыла.* Ф. Әмирхан. *Үрел, галим, яңа баскычка, Матдәнең ач яңа төрләрен.* М. Хөсәен.

3. *иск.* Аерым бүлек, параграф, пункт, статья. *Шушы өч матдәдән гыйбарәт карарнамә беравыздан кабул ителде.* Ш. Камал. *Иң ахырдан* [*гаепләүче*], *Вәли Хәсәновка килеп, аның җинаятен 57 нче матдәгә салып, йәштимагый саклауның иң югары чарасы бирелергә — атылырга тиешле, диде.* Г. Ибраһимов.

МАТЕМА'ТИК I *и.* Математика белгече. *Атаклы математик.* || *сөйл.* Математика укытучысы.

МАТЕМА'ТИК II *с.* Математикага бәйләнешле. *Математик формулалар. Математик анализ.* || *күч.* Математикадагыча төгәл, ачык. *Математик төгәллек.*

МАТЕМА'ТИКА *и.* Санлы зурлыкларны, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне, пространстводагы формаларны өйрәнә торган фәннәр җыелмасы. *Математика галиме.* □ *Мин хәзер калган дәресләремә бирелдем. Математикамны эшлим.* Н. Исәнбәт.

МАТЕРИАЛ *и.* **1.** Нәрсә дә булса хәзерләү, ясау өчен кулланыла торган предметлар, матдәләр; чимал. *Ике ташлы су тегермәне янына алар, үз көчләре һәм үз материаллары белән, җиде пычкылы такта ярғыч эшләгәннәр.* М. Гали. *Әйберне ясау яки төзәтү өчен корал һәм материал кирәк.* Г. Галиев.

2. Берәр нәрсәгә нигез, дәлил булып хезмәт итә торган чыганак; белешмәләр, фактлар. *Тарихи материаллар. Фәнни материал.* □ *Шул беренче материал аңа үзенең тикшерү эшен кайдан, ни рәвештә башлап китүнең планын төзергә тәмам җитте.* Г. Ибраһимов. *Яшь автор сәхнәбез өчен яңа булган тормыш материалы алып килә.* М. Әмир. || Нинди дә булса мәсьәләгә, эшкә караган документлар, язмалар, кәгазьләр җыелмасы.

3. Тукыма, материя (3 мәгъ.), *Костюмлык материал алу.*

МАТЕРИАЛИЗМ *и.* **1.** Идеализмга капма-каршы буларак, рухка, аңга, фикерләүгә мөнәсәбәттә материяне, табигатьне, объектив чынбарлыкны беренчел дип таный торган, объектив чынбарлыкның аңга, фикерләүгә бәйсез рәвештә яшәвен, дөньяны һәм аның закончалыкларын танып белүне икърар итә торган фәнни философик юнәлеш. *Материализмның иң югары формасы — Маркс һәм Энгельс тарафыннан нигезләнгән һәм В. И. Ленин тарафыннан үстерелгән диалектик материализм.* М. Абдрахманов.

2. Чынбарлыкка үтә практик, коры акыл күзлегеннән генә карый торган мөнәсәбәт. || Чынбарлыкка шәхси файда күзлегеннән генә карый торган мөнәсәбәт.

МАТЕРИАЛИСТ *и.* **1.** Философиядә материализм тарафдары.— *Материалист галимнәр карашында материя дигән нәрсә үзеннән-үзе мәңгедән-мәңге бар һәм мәңгедән-мәңге бетми.* Ш. Камал.

2. Чынбарлыкка үтә тар практик, коры акыл күзлегеннән генә караучы, идеальлекне, югары максатларны инкяр итүче кеше. *Мин материалист идем, дөньяда булган нәрсәләрне төрле матур буяуларга буямыйча гына, туры хакыйкать көенчә генә күргә ярата идем.* Г. Рәхим. || Һәрнәрсәне бары тик шәхси материаль файда күзлегеннән карап кына бәяләүче кеше.

МАТЕРИАЛИ'СТИК *с.* Материализмга нигезләнгән, материализм принципларын чагылдыра торган. *Дөньяга материалистик караш.* □ *Фәннең һәм шул исәптән материалистик философиянең алга үсеше хәзер дә бик күп каршылыкларга очрый.* М. Абдрахманов.

МАТЕРИАЛИСТЛА'РЧА *рәв.* Материалистларга хас булганча.— *Син бит комсомолец, Рифгать, һәр мәсьәләгә материалистларча карарга тиеш.* М. Әмир.

МАТЕРИАЛЛАШТЫРУ *и. кит.* Сиземләнә торган конкрет формаларда гәүдәләндерү. [*„Нота дәфтәре"*-нең басылып чыгуы], *музыкадан татарча беренче әлифба буларак, моңа хәтле әйтелгән идеяләрне, материаллаштырып, халыкка җиткерүдә җитди бер адым иде.* Г. Ибраһимов.

МАТЕРИАЛЛАШУ *и. кит.* Сиземләнә торган конкрет формаларда гәүдәләнү.

МАТЕРИАЛЬ *с.* **1.** Материягә (1 мәгъ.) бәйләнешле; аң, фикерләүдән тыш яши торган; физик, матди. *Шулай итеп, без тере организмнарның үзгәреше, үсеше аны чолгап алган материаль дөнья йогынтысында һәм шул йогынтыга яраклашу процессында барганын күрдек.* М. Абдрахманов.

2. Материалга (1 мәгъ.) мөнәсәбәте булган. [*Тикшерү нәтиҗәсендә*] *кайбер материаль җаваплы кешеләрнең өстенә зур гына суммаларга барып баскан җитмәүләр дә чыкты.* Ә. Еники.

3. Милеккә, эш хакына, табышка, яшәү шартларына мөнәсәбәтле. *Халыкның материаль һәм культура дәрәҗәсен күтәрү.* □ *Бөтен илнең материаль байлыгы, экономик куәте, машина техникасы искитәрлек тизлек белән үсә.* Г. Бәширов.— *Материаль шартлар тудыру һәм кешеләрнең психологиясен тәрбияләү коммуна рамкасында тизрәк һәм җиңелрәк эшләнәчәк.* Ш. Камал.

МАТЕРИАЛЬЛЕК *и.* Материягә (1 мәгъ.) хас үзлек. *В. И. Ленин болай дип күрсәтте: табигать белемендә килеп чыккан кискен үзгәреш дөньяның материальлеген - - - инкяр итми.* КПСС тарихы.

МАТЕРИК *и.* Диңгезләр, океаннар белән чолгап алынган бик зур мәйданлы коры җир; континент. *Африка материгы.* □ [*Утрауда*] *урман арасындагы яшел палаткаларга урнашып алу белән, материктан килгән командаларны взводларга, роталарга тараттылар.* Ә. Маликов.

МАТЕРИЯ *и.* **1.** *филос.* Кеше аңыннан тыш һәм аңа бәйсез рәвештә яши торган объектив чынбарлык. *Дөньяда хәрәкәтләнүче материядән бүтән һичнәрсә юк, һәм хәрәкәтләнүче материя, пространство һәм вакыт эчендә хәрәкәт итмичә, бүтәнчә хәрәкәтләнә алмый.* В. И. Ленин.

2. Физик җисемне тәшкил итә торган әйбер; матдә. *Материянең төзелеше.*

3. Тукыма. *Аның өстендә дә, минеке кебек үк, җиңсез челтәр күлмәк, арзанлы материядән тегелгән чалбар.* М. Әмир. *Ике тәрәзә арасында кызыл материя, өстенә чын урак белән чын чүкеч беркетелеп, чын ашлык башаклары белән бизәкләп куелган.* М. Фәйзи.

МАТЛУП *с. иск.* Таләп ителгән, тиешле. *Ерак шәһәрдән зур мәдрәсәгә барып кергәч, эшләр тагы да үзгәрде, әлбәттә, Зыя өчен матлуп булмаган якка таба!* Г. Ибраһимов. *Ислах дәрьясында йөзсен безнең кораб, - - - Матлуп җиргә сау-сәламәт җитешкәнче.* Г. Тукай.

МАТРАУ *ф. диал.* Бик каты тирләгән килеш эчерү аркасында атларда була торган аяк авыруы — аксау. *Хәйретдин карт - - - аяклары матраган бияне, яхшы тәрбияләү белән бергә, ныклап дәваларга да тырышты.* Ш. Камал.

МАТРАС *и.* Яту өчен махсус эшләнгән йомшак калын җәймә; көрпә. *Мамык матрас. Пружиналы матрас.* □ *Ул матрасы өстенә ятканкилеш укып та, чәй дә эчеп маташа.* Һ. Такташ.

МАТРАСЛЫК *с. сөйл.* Матраска яраплык; бер матраска җитәрлек. *Матраслык мамык.*

МАТРЁШКА *и. сөйл.* Рус крестьян хатын-кызы киемендә ясалган эче куыш агач курчак (гадәттә кечерәкләре зурракларының эченә урнаштырыла һәм эчтәк вакытта ачып алына). *Кыңгыраулар чыңлый, ямщиклар уза, Я матрёшкалар биеп китә кебек.* Н. Арсланов.

МАТРИАРХАЛЬ *с.* Матриархатка мөнәсәбәте булган. *Матриархаль ыруг. Матриархаль мөнәсәбәтләр.*

МАТРИАРХАТ *и.* Хуҗалык һәм җәмәгать тормышында җитәкчелек роле хатыннар (ана) кулында булган, хатыннар ягыннан кардәшлек нигезендә берләшкән борынгы ыруглык җәмгыять формасы. *Борынгы община строе үзенең иң югары дәрәҗәсенә матриархат вакытында ирешкән.* Политэкономия.

МА'ТРИЦА *и. махс.* Типографик литерлар, стереотиплар, акча кою һәм штамплау өчен чокып эшләнгән оялы калып. *Сенат типографиясендәге гарәп хәрефе белән коелган матрицалар - - - Казанга күчерелә.* И. Рәмиев. *Әхмәт Симаев [яшерен хатларны] тиз арада синтетик матрицага төшереп бирде.* Ш. Маннур.

Матрицага салу (сугу) — нәрсәнең дә булса матрицасын ясау. *Газета материалларын матрицага салу.*

МАТРИЦАЛАУ *ф. к.* матрицага салу (сугу).

МАТРОС *и.* Хәрби флотта, шулай ук хәрби булмаган суднода гади (командирлар составына кермәгән) хезмәткәр; диңгезче.— *Петроградта урам сугышлары бара, матroслар „Аврора"дан Кышкы Сарайга аталар.* Т. Гыйззәт. *Бер жандарм белән ике матрос, дебаркадердагы халык төркемен уңга да, сулга да эткәләп, уртадан ярып эчкә уздылар.* М. Гали.

МАТРО'СКА *и. сөйл.* Зур кайтарма якалы матрос блузасы. || Шундый фасонда тегелгән хатын-кызлар яки балалар блузасы. [*Рөстәмнең*] *өстендә өр-яңа ак матроска белән кыска ак чалбар иде.* А. Шамов.

МАТРОСЛА'РЧА *рәв.* Матрослар кебек, матросларга хас булганча. *Асия бүген матросларча киенгән иде.* С. Сабиров.

МАТРОСЛЫК *и.* Матрос хезмәте. *Саша Хәйдәрне үз пароходларына матрослыкка чакырды.* Г. Минский.

МАТУР *с.* 1. Күрер күзгә күркәм; буяуларның, бизәкләрнең, сызыкларның нәфислеге, гармониялелеге белән аерылып торган; чибәр (кешеләр турында). *Матур бакча. Матур йорт.* □ *Матур матур күренмәс, Сөйгән матур күренер.* Мәкаль. *Бизәклилләр җир өстен Чәчкәләр төсле матур кызлар.* М. Гафури. *Биҗрәк матур җәйге иртә, Биҗрәк матур җәйге таң!* М. Җәлил. || Ягымлы, игътибарны җәлеп итә торган (йөз, чырай турында). *Бабай бик күп яшь яшәгән, карт ул үзе, Ләкин һаман сәламәт ул, матур йөзе.* Г. Тукай. *Ул үзенең ал күлмәге, матур чырае белән бик зур гөл чәчәгенә охшый, ифрат та сөйкемле.* Ш. Камал. || Килешле, нәфис, гармонияле хәрәкәтләр белән аерылып торган. *Матур йөреш.* □ *Шәраф озак, матур фигуралар ясап, төрле сүзләр ычкындырып, дәртләнеп бии.* М. Фәйзи. | *рәв. мәгъ. Чибәр кызлар, шат кызлар Матур басып атлыйлар.* Ә. Ерикәй. || Ишетүгә ягымлы, нәфис яңгырашлы, аһәңле. *Равиль кыска, матур, җиңел көй уйнап җибәрә.* А. Әхмәт. *Рабиганың матур тавышы моңлы, назлы.* Ш. Бабич.

2. Теләк-омтылышларны тулы канәгатьләндерә торган; яхшы, күңелле. *Матур килэчәк. Матур дуслык.* □ *Дошманнар Нәгыймәнең Садыйк кочагында тапкан бу матур бәхетен көнләделәр.* Г. Ибраһимов. || *сөйл.* Хуплана, мактала торган, күркәм. *Алар, юл күрсәтеп сезгә, Матур эшләр көтә сездән.* М. Гафури. || Рухи канәгатьләнү, ләззәтләнү хисләре тудыра торган. *Өмет дигәнең күңелне җылытты, билгесез киләчәк турында матур хыяллар тудырды.* И. Гази. *Яза башладым исә, берсе-берсеннән матур тойгылар, фикерләр кәгазьгә агылырга гына торалар.* Г. Кутуй.

3. Сәнгатьле, нәфис. *Залның ике як стенасында күргәзмә. Анда рус һәм татар совет матур әдәбиятының үрнәкләре.* Ф. Кәрим.

4. *ирон.* Эффектлы, ләкин эчтәлексез, тышкы ялтыравык белән генә аерылып торган. *Төрлечә итеп алдап Иттеләр безне солдат, Төрле матур сүзләр белән Сугыштырдылар яллап.* Г. Камал. *Безнең кайбер язучыларыбыз үзләрендәге идея түбәнлеген яки идеясезлекне „матур форма", „матур сүзләр" белән капларга тырышалар.* Һ. Такташ.

5. *и. мәгъ. тарт. форм.* **матурым, матуркай(ым).** Иркәләп, якын итеп әйтелә торган мөрәҗәгать сүзе. *Синнән башка сөйгәнем юк, Ышанамсың, матурым.* Жыр. [*Селиванов Фәхриягә:*] — *Кара әле, матуркай, нишләп монда лампа тотып чуалып йөрисең?* Ш. Камал.

МАТУРАЙТУ *ф.* Матур төскә, сыйфатка кертү; матур итеп күрсәтү. *Поход, сугышлар алдыннан ул бер дә кырынмыйча калмый, иске, ләкин чиста шинеленең бөтен каптырмаларын каптырып, билен кысып буа, - - - матур сынын тагын да матурайтып, җыйнаклатып ала.* И. Туктар.

МАТУРАЮ *ф.* Матур төскә, сыйфатка керү; матур булып күренү. *Рокыяның Сөләйман алдында гына матураясы, аның алдында гына иркәләнәсе килә.* Ш. Әхмәдиев. *Чияләр дә, вакыты җиткәч, кызаралар, тулылыктан матураялар.* Г. Кутуй.

МАТУРЛАНУ *ф.* 1. Матураеп китү, матур төскә керү. *Ә кызларым һаман матурлана, Көнләшәм дә мин кай арада.* З. Мансур. *Алма пешә алланып, Матурланып, балланып.* Жыр. || Тулылану, тазару, төс керү. *Һәфисә хәзер тагын да тулыланып, матурланыбрак киткән кебек булды.* Г. Бәширов. — *Абый үзе тазарган, тагын да матурланган.* Т. Гыйззәт. || Рәхәт, тыныч, күңелле итеп яшәү мөмкинлекләре барлыкка килү; яхшыру (тормыш турында). *Тормышыбыз матурланды, Илебез алга бара.* Ә. Ерикәй.

2. Матур күренергә тырышып бизәнү, ясану. *Киендем, хәл кадәре матурландым.* М. Гафури.

МАТУРЛАУ *ф.* Матур итеп бизәү, кемгә-нәрсәгә төрле бизәкләр һ. б. ярдәмендә матур төс, күренеш бирү.— *Рабфак урынында Фәннәр академиясе! - - - Ә йортның үзен ничек матурлаганнар!* Р. Ишморат.

Парикмахер җаным, матурла син мине, Теләсәң ничек итеп матурла. Һ. Такташ. | *рәв. мәгъ.* [*Йортның*] *тәрәзә яңаклары, болдырлары матурлап, сырлап эшләнгән.* Г. Әпсәләмов. [*Кызның*] *коңгырт чәче матурлап кыскартылган.* Г. Ибраһимов. || Сәнгатьлерәк, бизәклерәк, купшырак, тәэсирлерәк итү (сөйләм, стиль турында). *Шигырьдә билгеле бер принцип саклану аны әдәби матурлый.* М. Җәлил.— *Сөйлә, Рәшат, син оста итеп, матурлап сөйли беләсең.* Ф. Әмирхан. || *күч.* Эчтәлеге ягыннан тулырак, баерак, җанлырак итү; кемгә-нәрсәгә эчке матурлык бирү. *Күлне камыш матурлый, Ирне намус матурлый.* Мәкаль. *Тагын шунда бу мәҗлесне матурлыйлар хатын-кызлар.* М. Гафури. *Кеше әйтте: — Бөтен елны Матурладым мин эштә.* Ә. Юныс.

МАТУРЛЫК *и.* **1.** Барлык матур, гүзәл, күңелгә рәхәтлек, ләззәт бирә торган нәрсә (күренеш, эш, тормыш, сәнгать әсәрләре һ. б.). *Язгы шатлыктан, матурлыктан халык уйный-көлә.* М. Гафури. *Без яшәгән илнең матурлыгын Йөрәк белән кирәк тоярга.* С. Хәким. || Матур, сокланырлык урыннар (табигатьтә, матур әдәбият әсәрләрендә). *Ул Идел буйларының бу матурлыгын күптән үк күреп йөри.* Г. Бәширов.

2. Матур, ягымлы, сөйкемле, үзенә нык җәлеп итә торган тышкы кыяфәт; чибәрлек. *Матурлык туйда кирәк, Мәхәббәт көн дә кирәк.* Мәкаль. *Матурлыгың белән мактанма, Батырлыгың белән мактан.* Мәкаль. || Кеше характерындагы, эшчәнлегендәге уңай, хуплана торган сыйфат. *Кошның матурлыгы төсенә карап, Кешенең матурлыгы эшенә карап.* Мәкаль.

МАТЧ *и.* Шахмат яки башка төрле спорт уенында ике каршы як яисә ике команда арасындагы ярыш. *Халыкара шахмат матчы. Футбол буенча илебез беренчелегенә чираттагы матчлар үткәрелү.*

МАТЧА *и.* Агач корылмаларда түшәм такталарын тотып тора торган дүрт кырлы аркылы борыс, өрлек. *Бу кәгазьләр матча ярыгына кыстырылып озак торганга шулай сарғайганнар бит.* Г. Бәширов. [*Клуб эчендә*] *матча саен кулдан язылган лозунглар эленеп тора.* А. Тимергалин.

МАТЧАЛЫК *и.* Матча өчен материал, бүрәнә. *Без ишек алдына күз салдык. --- Читән буенда имән өрлекләрдән матчалыклар ята, аларга янәшә түшәмлекләр сайлап куелган.* Г. Галиев. || *с. мәгъ.* Матчага яраклык. *Матчалык бүрәнә.*

МАТӘМ *и. кит.* Кеше үлү яки берәр ижтимагый фаҗига булу сәбәпле кичерелә торган зур кайгы, хәсрәт. *Фатыйма бикә, хөрмәтсезлек булыр дип, матәм көнендә кунакка йөрүне килештермәсә дә, кызы бик ялынып сорагач, туктатырга кыймады, җибәрде.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Матәмгә мөнәсәбәте булган; кайгылы, бик моңсу. *Оркестр соңгы мәртәбә Шопенның матәм маршын уйнады.* Ф. Хөсни. *Сафлан тыгыз, эшче халык, Тынсын инде матәм көе, Җырлыйк әйдә җиңү җырын.* Ф. Бурнаш.

◇ **Матәм тоту** — берәр фаҗига уңае белән тирән кайгы-хәсрәт кичерү, уен-көлке, күңел ачулардан тыелып тору. *Поляк милләте --- зур бер матәм тотарга мәҗбүр булды: Польшаның иң шөһрәтле вә гаять зур мәхәббәт казанган мөхәррире Генрих Сенкевич вафат булды.* Ф. Әмирхан.

МАҤУЗЕР *и.* Автомат пистолетның бер төре. *Ул биленә ялтыравык саплы хәнҗәр һәм маузер такан.* Р. Ильяс.

МАУЗУГ *и. иск.* Тема. [*Әдипнең*] *яңа башлап әйткән сүзе дә, теле дә, маузугы да икенчерәк иде.* Г. Ибраһимов. *Хөснетдин белән дә Мохтар сәяси маузугта сөйләшеп карады.* Ш. Камал.

МАХ(Ы): мах(ы) бирү — ялгышу, сынату, уңганлык-җитезлек күрсәтә алмау. *Хәкимем түргә, почетлы кунаклар янына китеп барды. Ә мин ... мин шунда гына үземнең нинди мах биргәнемне абайлап алдым.* С. Сабиров.— *Көн безнеке инде. Бик сак бул, малай. Мин махы бирдем, син бирмә инде.* М. Фәйзи.

МАХАУ *и.* Йогышлы тире авыруы; *русчасы:* проказа. *Сихерче махау дигән авыру белән авырганга, аңа алачыгыннан чыгарга ярамый иде.* Мең дә бер кичә.

МАХАУЛЫ *с.* Махау авыруы булган.

МАХИЗМ *и. филос.* XIX йөз ахырында философиядә һәм теоретик физикада реакцион субъектив-идеалистик агым. *Махизм философиясе, бигрәк тә алла төзүчелек, политикада реакция белән бергә кушыла иде.* КПСС тарихы.

МАХИНА'ЦИЯ *и. сөйл.* Берәр теләккә ирешүдә гадел булмаган ысул, астыртын хәйлә; шундый юл белән башкарылган эш. *Бөкре Хуҗиның Борһаннан башка эшләгән күп кенә махинацияләре ачылды.* М. Хәсәнов. *Бервакыт көрәк оны эшендә [Газизнең] ниндидер махинациясе сизелеп, Субай Кәрим дигән бик усал һәм ярлы бер крестьян белән болар арасында җәнҗәл куба.* Ш. Камал.

МАХИСТ *и.* Махизм тарафдары.

МАХМЫР *и. сөйл. к.* макмыр. *Подполковник белән обер-лейтенант, әллә курыкканлыкларыннан, әллә махмырдан дер-дер калтырап, --- без күрсәткән якка баралар.* Ә. Айдар. [*Талиповның*] *кыяфәте махмырдан аракы таба алмаган кешенеке төсле.* Ф. Яруллин.

МАХМЫРЛАУ *ф. сөйл. к.* макмырлау. *Бер көн бик нык махмырлаган һәнүз.* Каз. утл.

МАХМЫРЛЫ *с. к.* макмырлы. *Махмырлы кеше кебек йөрү.*

МАХОВИК *и. тех.* Механизмның тигез ритм белән эшләп торуын тәэмин итә торган авыр тугымлы тәгәрмәч. *Уң якта шартлатылган локомотив ята. --- Нәкъ юл читендә, сулда, дүрткә сынган маховик күренә.* А. Расих.

МАХО'РКА *и. сөйл.* Түбән сортлы тәмәке (тәмәке үсемлегенең сабакларын вак кыпа итеп турап ясала). *Шәмси махоркасын соңгы мәртәбә чытырдатып суырды да аяк астына ташлап чабатасы белән изде.* Х. Садрый.

МАХРА *и. гади с. к.* махорка. *Махра борып, икәү сөйли торгач, Колхоз хәбәрләрен сораштым...* Һ. Такташ. *Фәхри абзый аның янчыгына берничә тартырлык махра салды.* Г. Ибраһимов.

МАХСУС *с.* **1.** Кем яки нәрсә өчен генә аерым билгеләнгән. *Махсус эш киеме.* □ *Казарманың бер бүлемендә юллар остасы тора, икенче ягы эшчеләргә махсус иде.* Ш. Камал. *Аны факультетта ялкынлы активист, алдынгы җәмәгать эшчесе итеп таныдылар, махсус стипендиягә билгеләделәр.* Г. Ахунов. *Һәм томаулы килеш киттем шулай Кыз чакырган махсус урынга.* М. Җәлил. || Ашыгыч, җитди, кичектергесез; нәрсә өчен дә булса атап билгеләнгән. *Махсус йомыш. Махсус чаралар. Махсус утырыш.*

2. Берәр аерым фән, техника, һөнәр, сәнгать өлкәсенә генә караган. *Махсус программа. Махсус доклад. Махсус музыка белеме. Махсус сүзлекләр.* □ [*Ул*] *махсус мәктәпне бетергән шпион булган.* А. Шамов.

3. Аерым бер, үзенә бер төрле, үзенә башка. *Шәһәр белән авыл бер-беренә үзенә махсус җеп белән бәйләнгән.* Г. Нигъмәти. *Губерна шәһәрендә, өязләрдә, волостьларда махсус милли гөешмалар төзелә икән.* И. Гази.

4. Кемгә яки нәрсәгә генә хас булган. *Һәркемнең үзенә махсус ләззәт тапкан нәрсәсе буладыр.* Ш. Мөхәммәдев.— *Абайлап карагыз әле шул әхмәтләрен. Анда әллә нинди, авылга гына махсус матурлыклар бар.* М. Фәйзи.

5. *рәв. мәгъ.* Нинди дә булса аерым бер максат белән; атап. *Яшь килен — Камилә белән махсус таныштыр, якынлаштыр.* Г. Ибраһимов.— *Бу турыда сөйләшү өчен сезнең янга махсус килмәкче идем әле.* Р. Ишморат.

МАЧ *и. сөйл. к.* масть. *Кәрте, кәрте нинди Уңай төшеп тора, һәр мач сиңа бәхет Төбенен чишеп тора.* Ә. Фәйзи.

◇ **Мач бирү**—карта яки домино уенында иректән яки ялгышып каршы як файдасына йөреш ясау. [*Домино уйнаучыларның берсе:*] *Я, чык. Әйдә. Мин сиңа мач бирдем. Яса алты да алты.* Г. Камал. **Мач килү (төшү)** — 1) уңышлы, әйбәт, яхшы булу.— *Иртәгә дә аяз булмакчы икән. Бик әйбәт. Печәнчеләргә мач килә.* Ә. Еники. *Бу сорау шундый мач барып төште, Рифат башына суккан кебек туктап калды.* Н. Исәнбәт; 2) туры килү, ярау, ошау. *Без бер-беребезгә бик мач килә идек.* Г. Әпсәләмов.

МАЧИН *и. иск.* Кешесыман маймыл. *Карга — карчыганың азгыны, Мачин — кешенең азгыны.* Мәкаль.

МАЧТА *и.* 1. Корабта җилкән беркетү, югарыдан торып күзәтү, сигнал бирү һ. б. өчен утыртылган махсус җиһазлы озын багана, колга яки тимердән эшләнгән биек корылма. *Балтик диңгезеннән кораб килә. Мачтасында алсу байрагы.* Н. Баян. *Искәндәр мачтаны утыртты, җилкәнне корды.* Г. Минский.

2. *тех.* Төрле максатлар (электр чыбыклары элү, радиостанция антенналары ныгыту, сигналлар бирү һ. б.) өчен биек итеп эшләнгән корылма. *Һәр скважина саен телевизион мачталар тоту меңнәргә төшә.* Ш. Бикчурин.

МАЧТАЛЫ *с.* Мачтасы булган. *Без утырып килгән ике мачталы корабтан җилләр искән.* Ә. Маликов.

МАШ *и. сир.* Башня, манара. *Бу инде әсирләр лагере түгел. Дөньяны әндагы шикелле чәнечкеле тимер чыбык камап алмаган, почмакларда пулеметлы машлар һәм капкаларда кораллы сакчылар юк.* Ш. Маннур.

МАШИНА *и.* 1. Бер төр энергияне икенче төр энергиягә әверелдереп, берәр файдалы эш башкара торган механизм яки механизмнар җыелмасы. *Электрон-исәпләү машинасы. Авыл хуҗалыгы машиналары.* □ *Атка — солы, машинага — май.* Әйтем. *Типография залы уртасында басу машинасыннан бер-бер артлы, җилпәвеч канатларыдай булып, яңа елның беренче көне газеталары чыгып тора.* Г. Минский. *Шәһәр кырыендагы фабрикаларда ниндидер машиналарның тонык тавыш чыгарып эшләүләре ишетелә.* К. Нәҗми. || Эштә автомат төсле бик җитез һәм төгәл хәрәкәт итүче кеше турында. || *күч.* Механизм шикелле өзлексез һәм төгәл эш башкаручы оешма, учреждение турында.

2. Нинди дә булса механизм ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган транспорт төре (күпчелек — автомобиль). *Көзге кебек ялтырап ятқан асфальт юлдан туктаусыз йөк һәм җиңел машиналар үтеп тора.* А. Әхмәт.— *Идел өсләрендә пар машиналары йөртәләр.* Т. Гыйззәт. || *иск.* Тимер юл поезды. *Машиналар кычкырталар, семафор ачылмаса.* Җыр.

◇ **Машина каны** — нефть. *Без машиналар каны кара алтын аккан диңгез ярларында булдык!* Һ. Такташ.

МАШИНАЛАШТЫРУ *ф.* Җитештерүдә машина куллану, машина җайланмалары булдыру.— *Иптәшләр, „Кызыл йолдыз“ [колхозын] машиналаштыру, электрлаштыру өчен көрәшне башлыйбыз!* К. Тинчурин.

МАШИНАЛАШУ *ф.* 1. Машиналаштырылу (*төш. юн. к.* машиналаштыру). *Машиналашкан җирләрдә [алтынны кул белән юу] ысулы бетә бара.* М. Гафури.

2. Автомат рәвештә җитез һәм төгәл эшләргә, хәрәкәт итәргә күнегү. [*Алтын юучыларның*] *машиналашкан куллары тимер торбадан агып төшкән суларны уйнаталар.* М. Гафури.

МАШИНАЛЫ *с.* Машиналаштырылган, машиналар белән эшләүгә көйләнгән. *Машиналы хуҗалык. Машиналы индустрия.* □ *Машиналы киң ындырда Көчле җыр гөрләп торыр.* Ә. Ерикәй.

МАШИНАЛЬ *с.* Аңсыз рәвештә, иректән эшләнгән, механик. *Машиналь хәрәкәт.*

МАШИНА-ТРАКТОР: машина-трактор станциясе (МТС) — колхозларны авыл хуҗалыгы машиналары һәм тракторлар белән тәэмин итә торган дәүләт предприятиесе (1958 елда бетерелә). *Әнә уңдарак, тау үзәнлегендә, яңа шәһәрчектәй булып, машина-трактор станциясенең биналары күренә.* Г. Минский.

МАШИНАЧА *рәв.* Машина кебек җитез, төгәл хәрәкәтләр белән. *Бар да иелгән, бөгелгән килеш капчык-мазар бәйләп, төйнәп тораллар. --- Куллар машинача эшли, ашыгыч хәрәкәт.* Н. Исәнбәт.

МАШИНИСТ *и.* 1. Машина белән идарә итүче эшче.— [*Сабир*] *бит безнең машинист та, механик та, тимерче дә.* Р. Ишморат.

2. Поезд йөртүче, локомотивны идарә итүче тимер юлчы. *Шәйхаттар бабай кадәр үк озын гәүдәле, аның яшь чагындагы кебек үк таза гәүдәле машинист Хәлимне, аннары Шәйхаттар бабайны паровоздан күтәреп төшерде.* Г. Гобәй.

МАШИНКА *и.* 1. Берәр төрле эш башкару өчен зур булмаган прибор. *Машинка белән чәчен алганда, ваннада юындырганда Хәлим аңында иде. Кертеп салганнан соң аңын җуйды.* И. Гази.

2. *сөйл.* Язу машинасы. *Машинкада басылган текст.*

МАЭМАЙ *и.* Эт (балалар телендә). *Әллә салкын тигән, Маэмайлар да Авылларда шаулап өрмиләр.* Н. Баян.

МАЭСТРО *и. иск.* Төрле сәнгать өлкәсендәге атаклы кешеләрнең (композиторларның, рәссамнарның, дирижерларның) мактаулы исеме.— *Сез көлмәгез, маэстро, горурланырга аз гына булса да хакым бар иҫ минем.* М. Хөсәен.

МАЯ *и.* 1. Салып куйган, тупланган акча; акча фонды, капитал. *Мая туплау.* □ *Ибен тапкан егеткә тәңкә мая.* Мәкаль. *Мин хәзер үземнең --- бөтен маямны, көчне менә шушы эшне башкарып чыгу юлында сарыф итәм.* З. Бәширн. || Нәрсәнең дә булса башлангыч нигезе.— *Менә нәрсә, Шәрифҗан: безгә кораллы отряд оештырырга кирәк.— Якуб абый, отряднын маясы бар! Ун кеше. Ышна бодаен саклыйбыз.* И. Гази. [*Этисе аерылып яңа семья коручы улы Тимеригә бер бөтен ипи сузып:*] — *Менә, — диде, — игелеген күр, йорт-җиреңнең маясы шул булсын.* Г. Бәширов.

2. Тавык йомырканы бер урынга гына салсын өчен ояда калдырыла торган йомырка. *Гата биш йомырканы да эшләпәсенә салган, маяга берәрсе калсын да димәгән.* А. Алиш. *Маясыз тавык та йомырка салмый.* Мәкаль.

◇ **Мая мал** — төп фонд, нигез. **Маяга калдыру** — запас, үрчемлек калдыру. **Мая салу (салыну)** — башлап җибәрергә нигез, җирлек булдыру (булдырылу). *Сүз башларга мая салынган.* А. Таһиров.

МАЯК *и.* 1. Сигнал уты белән судноларга юл күрсәтү өчен диңгез ярларына, утрауларга куелган биек корылма, башня. *Менә Воронцов маягы артта калды. Озакламый Одесса да экренлән күздән югалды.* Каз. утл. || Елгаларда, кулларда, диңгез култыкларында суднолар йөрешле юлны һәм сай, куркынычлы урыннарны күрсәтү өчен якорь өстенә беркетеп куелган

йөзмә билге; бакен. *Илсөяр көймәне зәңгәр маякка таба борды һәм, җил арттан булганга, бусына килү алай авыр булмады.* Г. Гобәй. *Маяк хәзер, җиңелчә генә тирбәлеп, кызгылт нур чәчә иде.* Э. Касыймов. || Кышын адашмас өчен, юлның ике ягына утыртылган агачлар. *Телеграмм баганасы олы юлга маяк ул.* Җыр.

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса символы, билгесе. *Москва, син бит якты идеалларга Бара торган юлның маягы.* Ә. Ерикәй. [*Татар язучыларының*] *идеалында да „көч белән бергә гүзәллекне җыйган" кеше образына мәхәббәт якты маяк булып торды.* Г. Халит. || *күч.* Нинди дә булса эшкә юл күрсәткеч, юнәлеш. *Алда якты өмет-идеал, Шул маякка карап юлга чыгам мин.* И. Юзеев. *Безнең өчен маяк булды Ленин бабай юллары.* Җыр.

3. *күч.* Эштә яхшы үрнәк күрсәтүче хезмәт алдынгысы. *Колхоз маякларын райүзәккә озатырга килүчеләр арасында Шапырай карт та бар иде.* М. Хәсәнов.

МАЯКЛАУ *ф.* **1.** Маяклар куеп, утыртып чыгу. *Юлларны маяклау.*

2. *махс.* Маяклар ярдәмендә туры сызык үткәрү. *Мәктәп участогын маяклап чыгу.*

МАЯКЛЫ *с.* Маяклар утыртылган. *Маяклы юллардан юлчы бара, Печән белән күмгән чанасын.* Һ. Такташ.

МАЯКЧЫ *и.* Маякларга хезмәт күрсәтүче. *Маякчы карт, аргы яктагы бакенның фонарен кабызып, кире кайтып килә.* И. Гази. *Яр буенда маякчы өе күренде.* Х. Садрый.

МАЯЛЫК *и.* **1.** Башлангыч нигез итеп билгеләнгән фонд, капитал.

2. *с. мәгъ.* Мая (2 мәгъ.) итеп калдырылган. *Миңленисаның чуар тавыгы йомырка салмады, --- печән түшәп әзерләнгән оя буш та буш, маялык акбур йомыркасы да гел ялгыз.* Г. Минский.

МА'ЯТНИК *и.* **1.** Ритмик хәрәкәт тәэмин итү өчен бер башы хәрәкәтсез ноктага беркетелеп, авыр башы атынып, тирбәнеп торган җайланма. *Фуко маятнигы. Маятник тирбәлеше.* □ *Тик стенадагы сәгать маятнигы гына, салкын канлылык саклап, үзенең ритмын бозмыйча, тип-тигез текелдәп тора иде.* Ш. Камал.

2. Кесә һәм кул сәгатьләре механизмнарының ритмлы йөрешен тәэмин итеп, үз күчәрендә төрле якка хәрәкәт итә торган тәгәрмәч.

МА'ЯТНИКЛЫ *с.* Маятник хәрәкәтенә нигезләнгән, маятнигы булган. *Маятниклы сәгать.*

МАЯУ *и. иск.* Ялгау (өлешләп коеп ясала торган әйберләр турында). *Чың-чың иткән чынаяк фабрикта маямый эшләнер.* Н. Исәнбәт.

МАҖАР *и. иск.* Мадьяр, венгр. *Мажар солдаты торды да боларга кул бирде.* М. Гали.

МАҖАРА *и.* **1.** Күргән, баштан үткән кызыклы яки күңелсез хәл, көтелмәгән вакыйга. *Яралы кызыл-армеецлар Хәлимнең бөтен юл мажараларын елмаеп, кайбер урыннарда ай-яй диешеп тыңлап тордылар.* Г. Гобәй. *Рөстәм мажаралары белән мавыгып, тыштан көлеп йөрсәм дә, йөрәгем сызлый минем.* Г. Кутуй.

2. Хәвефле, куркынычлы, дәһшәтле хәл, вакыйга, фаҗига. *Агарып тора Кремль, Борынгы манарасы, Үткән аның башларыннан Тарихлар мажарасы.* Н. Исәнбәт.— *Тапкансыз икән өйләнеп йөрер чак. Мондый мажара көннәрендә нинди никах ул? — Кемгә ничек бит! Берәүләргә мажара, икенче берәүләргә дөнья яңара.* Т. Гыйззәт.

3. Очрак, хәл.— *Әмма бу юлы бөтенләй башка мажара. Бу юлы абыең бөтен дөнья кунагы җыйналып килә икән, анда да бер сүзем юк.* Ш. Камал.

МАҖАРАЛЫ *с.* Төрле мажараларны эченә алган. *Мажаралы хикәя.* □ *Кинотеатрда „Мисс Менд" исемле --- мажаралы фильм бара иде.* Ф. Хөсни. *Ул көнне төн бик мажаралы узды. Гыйззәтуллин ике тапкыр кычкырып уянды, --- Зарифуллин төшләнеп көлде.* М. Мәһдиев.

МАҢ *и. диал.* **1.** Киемнең эчке ягына (мәсәлән, күлмәк итәгенә, төймә тишекләре әйләнәсенә, чалбарның бил тирәсенә һәм балакларына) башка төрле материядән куелган тар астар; әдеп. *Маңның очын, төп тукымадан һәм маңнан ясалган киртләчләрне бөтенесен бергә машинада кайыйлар.* Йорт эшләре.

2. Капчык, пәрдә, ыштан кебек нәрсәләргә киндерә тагу өчен бөкләп тегелгән урын, бөрмә. *Җитез идем — җил идем, Җиде көндә бер ыштан тектем; Бавы бар да маңы бар, Җиде көнлек тагы бар.* Такмаза.

МАҢГАЙ *и.* **1.** Йөзнең яки хайваннар башының күздән югарыгы өлеше. *Маңгай чәче. Маңгай җыерчыклары. Киң маңгай. Текә маңгай.* □ *Башындагы киң эшләпәсен Маңгаена төшереп кигән ул.* М. Җәлил. *Дугаларга я кызыл байрак, я ике таяклы озынча кызыл комач беркетелгән, атларның маңгайларына да тасмалар тагылган.* Г. Гобәй. || Баш киеменең маңгай турысына килә торган өлеше. *Каршымда торган егетнең Маңгаенда йолдызы бар.* Ә. Ерикәй. *Офицерларның алтын-көмешле погоннары берртәттән өзелеп җиргә ташланды, маңгайдагы кокардалар йолкынып ыргытылды.* М. Гафури.

2. Тауның иң биек, текә урыны, кашы. *Маңгаенда тауның — кыя ташлар, Иягендә — зәңгәр урманнар.* Н. Исәнбәт.

3. *рәв. мәгъ., чыг. килеш форм.* **маңгайдан**. Туптуры, каршыга. *Маңгайдан бәр! — диде комиссар, Артына төш, ипташ партизан.* Х. Туфан. *Ут белән каплау группасы, маңгайдан барып, сазлык яки флангкарак тартылырга һәм шунда оборонага урнашырга тиеш.* Ф. Кәрим.

◇ **Маңгаена язылмаган (язулы булмый)** — тышкы кыяфәтеннән беленеп, күренеп тормый (кемнең кем булуы турында). *Эчке дошманнарның: „Бу дошман", — дип, Булмый маңгаена язулы.* М. Гафури. **Маңгай астыннан (аша) карау (күзәтү)** — башны аска иеп, усал итеп яки бик уңайсызланып карау; *к.* каш астыннан карау. *Эшче колонналары --- урам яңгыратып җырлап узган чакта, күкрәкләренә кызыл чүпрәкләр таккан байбәтчәләр, корсакларын киереп, маңгай астыннан бүредәй карап тордылар.* И. Гази. *Малайлар шыпырт кына көлешеп һәм качынып кына маңгай аша Габдулланы күзәтә башладылар.* Ә. Фәйзи. **Маңгай белән таш (стена) тишү (яру, вату)** — булдыра алмаслык, көчтән килмәслек эшкә алыну. *Маңгаем белән таш стенаны ватармын, ә Вәсимәне кешегә бирмәм.* Ф. Хөсни. **Маңгай ору** — баш иеп, тирән ихтирам белдерү, түбәнчелек күрсәтү. *Барысы да Камышлы мәчет мулласына сәдака бирергә, кулын үбеп, маңгай орырга, догасын алырга ашыкты.* Г. Минский. **Маңгай тире** — авыр физик хезмәт, тырышлык. *Алар байлар өчен көтү көткән, Маңгай тире белән көн иткән.* Ф. Бурнаш. **Маңгай тире агызу (чыгару, түгү)** — бик зур физик көч, эш сарыф итү.— *Хезмәт көне ул, билбөгеп, маңгай тире агызып эшләгәндә генә хезмәт көне!* А. Шамов. — *Ипекәй дигәнең безнең өйгә үз аягы белән тәпиләп кайтмый ул. Аны менә шулай, маңгай тирен чыгарып эшләп алырга кирәк.* Г. Бәширов. **Маңгай тире таму (сеңү)** — бик күп физик көч, эш сарыф ителү.

— Алпавыт малы синең малың түгел, ә халыкныкы! Аңа безнең ата-бабаларыбызның маңгай тире сеңгән. И. Гази. **Маңгайга бәрү (бәреп әйтү)** — *к.* йөзгә бәрү. **Маңгаена тай типмәгән** — юләр түгел, үз акылында.— *Сабирның кем икәнлеген үтәдән-үтә күрмәсәм, мондый эшне тапшырammыни мин. Маңгаема тай типмәган минем.* М. Әмир. **Маңгайга язу** — бик нык кисәтеп, хәтердә сакланырлык итеп әйтү, аңлату. *— Минем маңгайга язып җибәрделәр. Без Вәли этне беләбез. Андый ерткычларга якты кояш астында көн булмасын дип әйтергә куштылар.* Г. Ибраһимов. **Маңгайга язылу** — алдан билгеләнеп куелу. *Без барасы юллар — олы да юл, дә, як-ягына кәнаулар казылган. Безнең дә болай буласыбыз, дә, туган көнне маңгайга язылган.* Җыр.

МАҢГАЙГА-МАҢГАЙ *рәв.* Кара-каршы килеп. *Кәҗә тәкәләре, кое бурасы өстенә сикереп менеп, шунда маңгайга-маңгай сөзешә башладылар.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Маңгайга-маңгай бәрелешү** — кара-каршы сугышу яки көрәшү, бик каты бәхәсләшү, талашу турында. *Уйламаганда гына кайбер иске танышлар белән маңгайга-маңгай бәрелешеп алырга туры килде.* Ф. Хөсни.

МАҢГАЙЧА *и.* **1.** Йөгәннең маңгай турысындагы каешы.

2. *этн.* Хатын-кызларда маңгай турысына киелә торган бизәү әйбере.

МАҢГЫТ *и. иск.* Борынгы Болгар дәүләтен яулап алуда катнашкан монгол кабиләләренең берсе. *Ил яманы — маңгыт, кош яманы — оңгыт.* Мәкаль.

МАҢКА *и.* **1.** Борыннан килә торган лайлалы сыекча. *Мәхәббәткә маңка тими, сөртәсең дә үбәсең.* Мәкаль.

2. *күч. гади с.* Балалыктан чыкмаган, тәҗрибәсез һәм кулыннан эш килмәгән кешеләргә карата кимсетеп, мыскыллап әйтелә. *Гармонь уйный бер малай, гармонь өсләре калай. Сезнең ише маңкаларга ялынмыйбыз без алай.* Җыр.— *Без бер сукканда японнарның биш-унысын кырып салыр идек. Ә бу маңкаларның кулыннан ни килер!* Ш. Мөхәммәдев.

3. *к.* маңка авыруы. *Башны балта бозар, Елкыны маңка бозар.* Мәкаль.

Маңка авыруы — атларда һәм башка кайбер тояклы хайваннарда була торган йогышлы авыру; *русчасы:* сап.

◇ **Маңка малай, маңка борын (танау)** *гади с.* — үзеннән яшь кешегә кимсетеп, нәфрәт белдереп әйтелә. *Әхми, маңка малай, атасы белән яшьтәш картны башка вак ялчылар белән бер рәткә куя.* Г. Ибраһимов. **Маңка тавык (сарык)** *гади с.* — байлык, дәрәҗә, эш тәҗрибәсе ягыннан түбәнрәк булган кешегә кимсетеп, мыскыллап әйтелә. *Нәсимовның актыкта өстен булып калуы, бигрәк тә аның соңгы чыгышы Бикмөхәммәтевнең хөббе нәфесенә бәрелде. Ул күрше ложаларга ишеттереп: — Маңка тавык! — диде.* Ш. Камал.

МАҢКАЛАУ *ф. сөйл.* **1.** Борыннан туктаусыз маңка килеп тору (салкын тиюдән һ. б.).

2. Маңка авыруына дучар булу.

МАҢКАЛЫ *с.* Борыныннан туктаусыз маңка агып, күренеп торган. *Маңкалы бала.*

МАҢЛАЙ *и. сөйл. к.* маңгай. *Маңлае киң, сөйкемле карар күзгә.* Дәрдмәнд. *Сара, --- Газизнең башын тотып, үзенә таба ия һәм маңлаеннан үбә дә читкә тартыла.* Ф. Әмирхан.

МАҢЛАУ *ф. диал.* Маң салу, тар әдеп белән әдепләү.

МАһ *ы.* Эт чакырганда әйтелә.— *Маһ, Маһ, фью! Акбүздән бернинди дә җавап булмагач, ят кеше тагын бер кисәк ит ташлады.* Г. Гобәй.

МАҺИР *с. кит.* Оста, сәләтле. *Һәр фәнгә маһир икән менә бу ир.* М. Гали. *Кем нинди һөнәргә маһир, Шул тирәгә сырыша, Шул тармакта осталыгын Күрсәтергә тырыша.* Ш. Галиев. || *и. мәгъ.* Һөнәр иясе. *Маһирга бак! Күр син аның оста эшен!* Сов. әд.

МАҺИРАНӘ *рәв. иск. кит.* Осталык белән, осталарча. *Драманың --- икенче, өченче вә бишенче пәрдәләре бик маһиранә тасвир ителгән.* М. Гали.

МАҺИРЛЫК *и. кит.* Осталык, сәләтлелек.—*Балта эшен дә беләм. Барысыннан аз-маз маһирлыгым бар.* С. Рафиков. *Исхакның --- хәйләгә маһирлыгы юк иде, аның йөзә белмәвен бик тиз күреп алдылар.* А. Гыйләҗев.— *Сәүдә эшләре дә — зур маһирлык, зиһенлек сорый торган һөнәр.* А. Расих.

МАҺИЯТ *и. иск. кит.* **1.** Нәрсәнең дә булса табигый хәле, табигый сыйфаты. *Бу хәл билгеле бер дәирәнең яман ниятеннән генә туган нәрсә түгел, бәлки буржуаз төзелешнең бөтен барлыгыннан, бөтен маһиятеннән туган нәрсә иде.* Ф. Әмирхан.

2. Нәрсәнең дә булса төбе, чыны, үзләге, асылы. *Революция үзе вә аның башлыклары безгә, тарихның маһиятен ачып биреп, тарихи процессның сыйныфларның көрәшеннән торганын белдерделәр.* Х. Госман.

МЕ'БЕЛЬ *и.* Бүлмә җиһазлары (өстәл, урындык, диван, шкаф һ. б.). *Мебель ясау мастерское.* □ *Чуар пыялалар белән бизәкләтеп эшләнгән зур тәрәзәдән кабинеттагы авыр мебельләргә йомшак якты-лык сибелә.* К. Нәҗми. *Мәдинә, матур итеп җиһазланган эш бүлмәсенең уртасына туктап, кулларын уып, зәвык белән сайланган --- мебельне карап торды.* А. Расих.

МЕ'БЕЛЬЧЕ *и.* Мебельләр ясаучы оста.

МЕГА- Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) сүзнең икенче өлешендә күрсәтелгән төп үлчәү берәмлегеннән миллион тапкыр зуррак, мәсәлән: **мегаватт, мегагерц;** 2) бик зур, гигант күләмле, мәсәлән: **мегалит, мегаспоралар.**

МЕГАГЕРЦ *и. махс.* Бер миллион герцны эченә алган тирбәлеш ешлыгын үлчәү берәмлеге. *Ай өстендәге станция белән радиоэлемтә тотрыклы. Тапшыру 183, 538 мегагерц ешлыкта алып барыла.* Соц. Тат.

МЕГАФОН *и.* Тавыш көчәйткеч җайланма. *Эч сереңне аларга сөйләгәнче, урамга чыгып, мегафон аша кычкырганың яхшырак.* М. Маликова.

МЕД- Кыскартылган кушма сүзләрдә „медицина“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **медпункт, медсанбат, медэкспертиза.**

МЕДАЛЬ *и.* **1.** Нинди дә булса сурәте, язуы булган һәм (эштә, фәндә һ. б.) зур хезмәт күрсәткечләре яки сугыштагы батырлыклар өчен бирелә торган металл түгәрәктән гыйбарәт билге. *Аның ике як күкрәге дә орденнар, медальләр белән бизәлгән.* Г. Гобәй. *Күрдем бу бөек сугышның иң соңгы күкрәвен дә, Берлинны алган өчен дә медаль бар күкрәгемдә.* К. Нәҗми. || Мәктәпне иң югары билгеләргә тәмамлаган укучыларга, шулай ук конкурсларда, спорт ярышларында һ. б. ш. җинеп чыгучыларга бирелә торган шуна охшашлы билге. *Урта мәктәпне алтын медаль белән тәмамлау. Авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә көмеш медаль белән бүләкләну.* || Берәр зур тарихи вакыйга яки аерым күренекле шәхес истәлегенә багышлап чыгарылган шундый билге. *Немец фашистларын тар-мар итүнең 20 еллык истәлегенә чыгарылган медаль.*

2. *иск. сөйл.* Революциягә кадәрге Россиядә авыл старостасы муенына тагып йөри торган калай жетон. *Ул арада, комган төбе чаклы җиз медален тагып, кулына таягын тотып, зур кара сакаллы, тупас битле староста да килеп җитте.* М. Гали.

◇ **Медальнең икенче ягы** — нинди дә булса эшнең икенче (гадәттә кире) ягы.

МЕДАЛЬОН *и.* Эченә рәсем куеп яки башка нәрсә салып, муенга тагып йөртелә торган кечкенә, түгәрәк яисә озынча түгәрәк тартмачык формасындагы зиннәт (ювелир) әйбере. [*Гөлсем апа*] *бер тапкыр --- Марат әнисенең медальонындагы рәсем кебегрәк киенеп кайтты.* Г. Гобәй.

МЕДИА'НА *и. мат.* Өчпочмакның түбәсен каршы яткан кырның уртасы белән тоташтыра торган туры сызык.

МЕДИА'ТОР *и.* Кайбер кыллы музыка коралларын уйнаганда кылларны чиертү өчен кулланыла торган бер башы очлы махсус юка пластинка кисәге; чиерткеч. *Һилалов --- медиаторны гажәп бер осталык, матурлык белән йөртә.* Ж. Фәйзи.

МЕ'ДИК *и.* Медицина белгече. *Нинди генә шартларда булсам да, мин — фельдшер, мин — медик.* Н. Фәттах.

МЕДИКАМЕНТ *и.* Дәвалау чарасы, дару. [*Врач:*] *Авыруларны дәвалау — безнең эш. Һәм авыруга нинди медикаментлар бирүне уйлау да.* Ш. Хөсәенов.

МЕ'ДИУМ I *и.* Спиритларның ышанулары буенча, кешеләр белән „рухлар" дөньясы арасында арадашлык итүче зат.

МЕ'ДИУМ II *и. муз.* Хатын-кызларның җырлау тавышында урта регистр.

МЕДИЦИ'НА *и.* Авырулар, аларны кисәтү һәм дәвалау турындагы фәннәр җыелмасы.— *Киләчәк медицинасы дәвалау медицинасы булып түгел, бәлки профилактика, чирләрне булдырмау медицинасы булып үсәргә тиеш.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Медицинага мөнәсәбәтле. *Медицина хезмәткәрләре. Медицина фәннәре.* □ *— Сезгә тиз арада медицина ярдәме кирәк, әгәр минем шул ике соравыма җавап бирсәгез, без ярдәм күрсәтербез, — диде офицер.* А. Расих.

МЕДПУНКТ *и.* Медицина ярдәме күрсәтү урыны. *Клуб тәрәзәләреннән сузылган яктылык, урамны кисеп чыгып, медпункт йорты стеналарына ук төшкән.* М. Шәфигуллин.

МЕДСАНБАТ *и.* Медицина-санитар батальоны, шулай ук бу батальонга караган медицина ярдәме күрсәтү урыны. *Полк командирына Потаповны ял итәргә һәм дәваланырга медсанбатка озатырга кушкан идем.* Каз. утл.

МЕДСЕСТРА *и.* Дәвалау учреждениеләрендә махсус урта белемле хезмәткәр. *Урта буйлы, 25—28 яшьләр тирәсендәге хатын врач, медицина капитаны, елмаеп миңа карап тора. Аның янында яшь кенә медсестра.* Ә. Айдар.

МЕДУ'ЗА *и. зоол.* Койка сыман тәнендә озын кармавычлары булган диңгез хайваны. *Агач тамырлары, диңгез төбендәге медузалар шикелле, кармавычларын ераккa сузганнар.* Ә. Маликов.

МЕЖА *и. к.* ызан. [*Тарантаслы кеше*] *арыш басуы межасына каерып керде дә туп-туры авыл уртасына таба юл тотты.* Г. Галиев.

МЕЖАЛАУ *ф.* Межа белән аеру, бүлеп чыгу; ызанлау. *XVIII йөздә авыллар арасында җир низаглары күбәя, бер авыл җире белән икенче авыл җире арасындагы межалар билгеләнмәгән була. Хөкүмәт бу низагны бетерү өчен 1757 елда межалау инструкциясе чыгара.* Каз. утл.

МЕЖАЛАШТЫРУ *ф. к.* межалау. *„Генераль межалаштыру акты" [1765 ел] дип аталган акт буенча [Идел буе] крестьяннарының җирләре рус алпавыт-колонизаторларына беркетелгән.* СССР тарихы.

МЕЖАЛЫ *с.* Межаланган, межалар белән бүлгәләнгән; ызанлы. *Авылга сугыш башлану турында хәбәр килеп җитә. --- Кешеләр, изге тирләре тамган межалы басуларын ташлап, авылга ашыгалар.* Каз. утл.

МЕЗДРА *и. махс.* **1.** Тиренең эчке ягындагы йомшак ярысы. *Сатып алучылар --- кайсы яка, кайсы каракүл тиреләре карыйлар, Әбелфәрит аларга йонын, мездрасын мактый.* Г. Әпсәләмов.

2. Күннең яки тиренең эчке ягы.

МЕЗОЗОЙ *и. геол. к.* мезозой эрасы.

Мезозой эрасы (чоры) — җирнең геологик тарихында дүртенче эра (палеозой һәм кайнозой арасындагы урта эра). *Ниһаять, мин хәзер бөтен көчне очыкырые күренмәгән мезозой чорына сарыф итүдән котылачакмын.* Н. Фәттах.

МЕЗОН *и. махс.* Массалары электрон массасыннан зуррак, протон массасыннан кечкенәрәк булган элементар кисәкчекләрнең гомуми атамасы. *Без монда электромагнит дулкыннары урынына мезоннардан файдалануны яхшырак күрәбез.* Каз. утл.

МЕЗОНИН *и.* Өй өстенә ясалган кечкенә корылма, чарлак. *Җәй өчен [йортның] тагы бер уңай ягы бар икән: чормаларына мезонин сыман бер бүлмә ясап куелган.* Э. Касыймов.

МЕЗОНИНЛЫ *с.* Мезонины булган. *Мезонинлы яңа дача. Бакча. Аскы якта Фәритнең верандалы квартирасы.* Ә. Фәйзи.

МЕКЕРДӘҮ *ф.* Мекер-мекер итү. [*Илдар*] *уйнаклап йөргән колыныңың, аңар җавап итеп, матур мекердәп, әнисе янына йөгереп килүе турында сөйли.* Г. Гобәй.

МЕКЕР-МЕКЕР *аваз. иярт.* Кәҗә, бәрән яки колынның йомшак кына бакыру яки кешнәү тавышларын белдерә. *Гыйният абзый белән [Дарья җиңги түбән очтан] кайтып килләләр. Кәҗәләре мекер-мекер арттан өстерәлә.* Г. Гобәй.

МЕ'КСИКАЛЫ *и.* Мексика кешесе.

МЕЛАНХО'ЛИК I *и.* Меланхолик II (1 мәгъ.) темпераментлы кеше. *Иң авыры рус теле, дибез. Юк, алай түгел, иң авыры психология! Аты коргыры фән! Меланхолик, сангвиник, холерик, флегматик, имеш.* М. Мәһдиев.

МЕЛАНХО'ЛИК II *с.* **1.** Эмоциональ кичерешләрнең акрын башлануы, ләкин тирән һәм дәвамлы булуы белән характерлана торган.

2. Меланхолиягә (1 мәгъ.) бирелүчән; боегучан, боек, төшенке күңелле. [*Муса*], *биш көн һичкая кузгалмыйча, шул меланхолик хәлендә калды, --- дөньяга күз дә салмыйча, урынында ятты.* Ш. Маннур.

МЕЛАНХО'ЛИЯ *и.* **1.** Төшенке күңеллелек, ямансулы рухи халәт, боеклык. *Беран бу көннәрдә мескен кыяфәт белән йөри. Меланхолиягә бирелеп, көннәр буенча, яккан мичкә аркасын сөяп утыра иде.* Ш. Усманов. *Тиз йөрешле „Ракета"да таныш түгел юлчылар белән шау-гөр килеп кайту үзе бер хозурлык бирә, меланхолиягә урын калдырмый.* Ф. Хөсни.

2. Сәбәпсез күңел төшенкелегенә бирелү, хәтта кайвакытта бер үк нәрсә, идея белән саташу дәрәҗәсенә җитүгә бәйләнгән психик авыру.

МЕЛА'ССА *и. махс.* Кара кызыл төстәге куе сыекча, чөгендер-шикәр производствосы калдыгы; чөгендер түбе. *Азык промышленносте калдыклары — барда,*

түп, меласса --- терлек азыкларын тулыландыруның әһәмиятле чыганагы була алалар. Соц. Тат.

МЕЛИНИТ *и. хим.* Сары төстәге көчле шартлаткыч матдә.

МЕЛИНИТЛЫ *с.* Мелинит салынган, мелинит катнаштырылган. *Мелинитлы снаряд.*

МЕЛИОРАТИВ *с.* Мелиорациягә мөнәсәбәте булган. *Мелиоратив эшләр.* || Мелиорация өчен билгеләнгән. *Мелиоратив машиналар. Мелиоратив корылмалар.*

МЕЛИОРА'ТОР *и.* Мелиорация белгече. *Җәүдәт Мансуров --- үзенә җир төзүчеләр, агроном һәм мелиораторлар ияртә дә көннәр буе кырларда, урманнарда, болын буйларында йөри.* Г. Бәширов.

МЕЛИОРА'ЦИЯ *и. а.-х.* Иген игүгә яраклы хәлгә китерү һәм ундырышлылыгын арттыру өчен коры һәм эшкә яраксыз җирләрне сугару, сазлыклы урыннарны киптерү эше. *Мелиорация белгече. Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгы.*

МЕЛИОРА'ЦИЯЛӘҮ *ф. а.-х.* Мелиорация үткәрү. *Җирләрне мелиорацияләү.*

МЕЛИ'ССА *и. бот.* Сары чәчәкле, лимон исле, баллы үлән үсемлек; лимон бөтнеге.

МЕЛЛА *и. иск. к.* мулла.— *Кара әле, мелла Закир, мин болай кунак булырга килмәгән идем бит.* Ф. Әмирхан.

МЕЛОДЕКЛАМА'ЦИЯ *и.* Музыка кушмалыгында башкарыла торган сәнгатьле уку. *„Сагыну" нәсерен мелодекламация итеп сөйләү.*

МЕЛО'ДИК *с.* Мелодиягә мөнәсәбәте булган. *Җырның мелодик төзелеше.* □ *Остазының сүзенә карагында, Хәбир, мелодик сәләте булуга карамастан, форма белән логиканы тоймый.* Ш. Хөсәенов.

МЕЛО'ДИКА *и. сәнг.* **1.** Мелодия турындагы фән.

2. Берәр композиторның, халыкның музыкаль иҗатына яки музыка әсәренә хас мелодик чаралар жыелмасы; нәрсәнең дә булса музыкаль төзелеше. *Моңа чаклы ул ясаган тальянкаларның тембр диапазоны татар җыр калыбына, аның мелодикасына туры килеп бетмәгән икән шул.* Каз. утл. [*Х. Туфан*] *шигырьләренең мелодикасында да, көйләнүчәнлек лирикасыннан бигрәк, сөйләү һәм декламация тибындагы лирика күпчелек урын ала.* Г. Нигъмәти.

МЕЛО'ДИЯ *и.* Музыкаль бердәмлек тәшкил итә торган билгеле бер авазлар чиратлашуы. *Сәйдәшнең беренче [иҗат] дәверендә характерлы як — гармониядән бигрәк мелодиягә күп игътибар бирү, көй өстендә эшләү булды.* М. Җәлил.

МЕЛОДРА'МА *и.* **1.** *иск.* Җырлы һәм музыкалы драма. *Совет мелодрамасы жанрында бер әсәр язып карарга бик кызыгам.* К. Тинчурин.

2. *әд.* Күпертеп күрсәтелгән авыр кичерешләргә, драматик тышкы эффектларга, үгет-нәсихәткә корылган драма жанры; шундый жанрдагы әсәр.— *Хәтта иң начар мелодрамаларда да болай еламыйлар бит, Идмас, — диде Акчурин хатынына, тирән шелтә белән.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Урынсыз трагизм, ясалмалык белән аерылып торган нинди дә булса вакыйга, хис, кичерешләр турында.

МЕЛОДРАМАТИЗМ *и. кит.* Берәр нәрсәне сурәтләүдә мелодрамага (2 мәгъ.) хас артык хискә бирелүчәнлек, ясалмалылык. *Без биредә кайбер шагыйрьләр иҗатында күңел төшенкелеген, сагышны, аерылышуны күрсәтүнең мелодраматизмга, „кичереш натурализмына" барып тоташуын, үзмаксатка әйләнеп китүен күздә тотабыз.* Каз. утл.

МЕЛОДРАМА'ТИК *с.* Мелодрамага мөнәсәбәте булган, мелодрамага хас. *Мелодраматик роль.* □ *„Зәңгәр шәл" — мелодраматик ситуацияләргә нигезләнеп язылган әсәр.* Б. Гыйззәт.

МЕЛОМАН *и. кит.* Җыр һәм музыканы бик яратучы. *Менә [Мәдинә] тачкылдап торган меломанга әйләнеп китте. Башкаларга үрнәк булырлык хирыслык белән, симфоник концертларга йөрде.* Ш. Хөсәенов.

МЕЛОМА'НИЯ *и. кит.* Җыр һәм музыкага (гадәттә опера музыкасына) чиктән тыш бирелү хәле.

МЕЛТЕК *с. диал.* Карсак, тәбәнәк буйлы. *Өченче иптәшем — Вәли дигән татар малае. Монысы безнең Муллагали кебек бер мелтек кенә нәрсә.* А. Расих.

МЕЛТЕРӘҮ *ф. сөйл. к.* мелт-мелт итү. [*Сәлим бабайның*] *иреннәре мелтерәп китте.* Н. Исәнбәт.

МЕЛТ-МЕЛТ: мелт-мелт итү — 1) күз кабакларын һәм иреннәрне ирексездән бик еш ачып-йомып тору. *Мөршидә авызын мелт-мелт итеп тора да кинәт елап җибәрә.* Т. Гыйззәт. *Карт күзләрен мелт-мелт итеп йомып куйды.* Ш. Камал; 2) тирбәнеп торган яки өзек-өзек зәгыйфь яктылык чыгару. *Машинаның мелт-мелт итеп барган кызыл утына ачуланып, нәфрәтләнеп карады кыз.* А. Гыйләҗев.

МЕЛЬХИОР *и.* Никель белән бакыр катнашмасыннан торган көмеш сыман коелма. || *с. мәгъ.* Шундый коелмадан эшләнгән. *Кухняда тәртипсезлек хөкем сөрә иде: чынаяклар чәйдән саргайган, мельхиор калаклар күгәргән.* М. Маликова.

МЕМБРА'НА *и. физ., тех.* Электр тирбәнешләрен һәм механик тирбәнешләрне тавыш тирбәнешләренә һәм киресенчә әверелдерүдә кулланыла торган яры яки сыгылма материалдан эшләнгән юка пластинка. *Зифа телефон трубкасын өстәлгә ыргыта, мембранада хахылдап көлгән тавыш бүлмәгә ишетелеп тора.* Н. Исәнбәт.

МЕМБРА'НАЛЫ *с.* Мембрана белән эшли торган. *Мембраналы реле.*

МЕМОРА'НДУМ *и. рәс.* Берәр мәсьәлә буенча хөкүмәтнең карашын белдергән дипломатик документ. *Совет хөкүмәте меморандумы.*

МЕМОРИАЛЬ *с.* Берәр тарихи вакыйганы яки атаклы кешенең истәлеген мәңгеләштерә торган. *Мемориаль корылма. Мемориаль музей. Мемориаль такта.* □ *Владимир Ильич туган урында төзәлүчәк мемориаль үзәк зур политик һәм тәрбия эшләре, Ленинның революцион идеяләрен пропагандалау үзәге булачак.* Каз. утл.

МЕМУАР *и.* Үткән вакыйгалар турында шәхси истәлекләр формасында язылган әдәби әсәр. *Бөек Ватан сугышы турындагы мемуарлар.* || *с. мәгъ.* Мемуар жанрына караган. *Мемуар әдәбият — иҗат эшенең үзенчәлекле тармагы.* М. Мәһдиев.

МЕМУАРЧЫ *и.* Мемуарлар язучы.

МЕНБӘР *и. иск.* **1.** Мәчет әчендә мулла, имам хөтбә укый торган баскычлы биек урын. [*Мулла*] *тәсбихләрен алып менбәргә менә һәм, күзләрен йомып, тәсбих тарта башлый.* Һ. Такташ.

2. *иск.* Трибуна, кафедра. *Бу төркемнең сәяси һәм иҗтимагый программасы бар. Ул программа — татар буржуа хәрәкәтен бер җиргә оештыру һәм, --- Дума менбәрләренә хәтле менеп, үз теләкләрен әйтү һәм үткәрергә тырышудан гыйбарәт.* Г. Нигъмәти.

МЕНГЕ *с.* Атланып йөрү өчен генә тотыла торган. *Менге ат.* | *и. мәгъ. Бераздан мин Каракошны яраулардыру эшенә керештем. Җикмәдем, менгегә генә тотарга булдым.* М. Хәсәнов.

МЕНГЕЗҮ *ф. к.* мендерү. *Керләрне чайкап бетергәч, Габдулла аларны кәрзингә тутырып ярга менгезеп куйган.* Э. Фәйзи. *Чуваш [карабодайның] ---*

бәһасен сиксән дүрт тиенгә менгездермәкче була. Ф. Әмирхан.

МЕНГЕРҮ *ф. к.* мендерү.— *Кара әле, Максимов, әйт әле син анда: ашны миңа монда гына менгерсеннәр!* А. Шамов. *Хәлимне вагонга тартып менгерделәр.* Г. Гобәй. *Мине Алмачуарга күтәреп менгерделәр.* Г. Ибраһимов.

МЕНГӘШТЕРҮ *ф. диал.* Атка үз яныңа тагын бер кеше атландыру. *Мин аларга хәлне аңлаткач, аларның берсе мине, үзенең атына менгәштереп, теге якка алып чыкты.* М. Гафури.

МЕНГӘШҮ *ф. диал.* Атка икә кеше атлану. *Менгәшмә, менгәштеңме, артың авыртса да эндәшмә.* Әйтем.

МЕНДЕРҮ *ф.* **1.** Югары урынга урнаштыру, күчерү (күтәреп, ат яки машина белән) яки берәр төрле җайланма, механизм ярдәмендә күтәрү. *Һәр көнне иртән, аз гына яктыра башлау белән, Нәфисә кызыл байракны чүмәлә өстенә мендереп кадый.* Г. Бәширов. *Шанны аркан белән тартып югары мендерергә ирләрнең генә көче җитмәде.* Ш. Камал. || Югары урынга күтәреп яки берәр төрле транспортта ташу. *Ул яшь чагында грузчик булган. --- Тәтеш ярлары өстенә тонна-тонна йөкләр мендергән.* М. Әмир. *Хәлим белән бабай калган агачларны, паровозның тендерына мендереп, бер читкә әрдәнәләп өеп куйдылар.* Г. Гобәй. || Нәрсәне дә булса югарыга таба күтәрү, күчереп кую. *Күзлекне маңгайга мендерү.* □ *Ул инде бишәр потлы капчыкларны, „эһ" тә итмичә, үзенең калын, таза җилкәсенә мендереп төшерә ала.* М. Гали.

2. Кая да булса менәргә, менеп утырырга ярдәм итү. *Җитәкләп мендерү. Вагонга мендерү.* □ *Ильинны, көтеп алып, көймәгә тартып мендердек.* Ә. Айдар.

3. Атландыру (атка). *Патшадан фәрман килеп төшүгә, әллә ничә егетне ат мендереп басуга чыгардылар да кычкырып --- һәммә халыкны куып кайтардылар.* Г. Ибраһимов. [*Хан кызы*] *үзе бер атка, Шаһзадәне икенче атка мендереп, икесе янәшә шәһәр капкасына таба киттеләр.* Ш. Мөхәммәдев.

4. Арттыру, үстерү (эш хакын, бәяне, капиталны, табышны һ. б.). *Бер миллионлы байның [теләге] — акчасын ике миллионга җиткерү (йөз меңләненке — ике-өч йөз меңгә мендерү).* Г. Тукай.

5. *күч.* Властька, югарырак ижтимагый дәрәҗәгә, яхшы эш урынына иештерү; эшендә күтәрү.— *Мирвәли абый белән Айсылу җиңгигә рәхмәт инде, алар мине бу дәрәҗәгә мендерде.* Т. Гыйззәт. *Сәфәргалинең хезмәте андагы зур начальникларга ошаган. Шуның өчен аны фельдфебель чинына мендергәннәр.* М. Гафури. || Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсендә күренекле, мактаулы итү, шундый хәлгә китерү. *Аның „Хикәяләр төркеме" һәм эшчеләр тормышыннан алынып язылган романтик повесте — „Акчарлаклар" Ш. Камалны шул заман татар әдәбиятының алдынгы сафларына мендерделәр.* Г. Нигъмәти.

6. *күч.* Кую, тамашачыларга уйнап күрсәтү (сәхнә әсәрләре турында). *Бездә театр китапларына да хәзер кытлык килде. --- Аптырагач, оеша алмаган тәрҗемәләрне сәхнәгә мендерергә мәҗбүр булалар.* Ан.

МЕНДӘР *и.* **1.** Баш астына салу яки аска куеп утыру өчен дүртпочмаклы тышлыкка мамык, йонмамык, кыл һ. б. ш. тутырып эшләнгән йомшак әйбер. *Сәкенең өстенә киез җәелгән, стена буена сандыклар, юрганнар, мендәрләр тезелгән.* Г. Ибраһимов. *Ак мамык мендәрнең Эченә күмелеп, Ул йоклый...* М. Җәлил. *Хәзрәт үзенә әзерләнгән мендәрләр өстенә утыра.* М. Гафури.

2. Иярнең ат аркасына тиеп торган йомшак өлеше. *Ияр мендәре.*

3. *тех.* Төрле корылмаларда, механизмнарда һ. б. нигез, терәк.

4. Арбаның ал күчәре өстенә куелган агач терәк. *Арба мендәре.*

МЕНДӘРЧЕК *и.* **1.** Кечкенә мендәр. *Энә мендәрчеге.*

2. *зоол.* Имезүче ерткыч хайваннар һәм кайбер кимерүче җәнлекләрнең бармакларында тиречел йомшак төер. *Мәченең аяк бармакларында тиречел йомшак мендәрчекләр була, шуның аркасында ул азыклыгына тавышсыз-тынсыз гына килә ала.* Зоология.

МЕНЕМГӘ: менемгә өйрәтү *диал.* — яшь атны атланып йөрергә өйрәтү. *Айгырым сыналмаган түгел. Өченче яшенә чыккач та менемгә өйрәттек.* Г. Ибраһимов.

МЕНЕШЛИ *рәв.* Менгән уңайга, менеп барганда. *Трапка менешли югартын күз ташлаганда, милиционер миңа тагын бер елмайды.* С. Баттал.

МЕНЗУ'ЛА *и. махс.* Җир өстенең планын һәм картасын төшергәндә кулланыла торган геодезик прибор.

МЕНЗУ'РКА *и.* Сыекчаларның күләмен үлчәү өчен кулланыла торган бүлемле (шкалалы) пыяла савыт. *Алар, кесәләреннән җәлпәк дару шешәләре чыгарып, мензуркаларга спирт салдылар.* Ш. Маннур.

МЕНИНГИТ *и. мед.* Ми тышчаларының шешүе, ялкынсынуы. *Башлангыч мәгълүматларга караганда, авыру менингитка охшый.* Каз. утл.

МЕНСТРУА'ЦИЯ *и.* Хатын-кызларда ай саен аналыктан кан килү хәле; күрем, айлык.

МЕНТОЛ *и.* Бөтнек исе аңкытып торган үтә күренмәле кристалл матдә (медицинада, парфюмериядә һәм кондитер әйберләре хәзерләү эшендә кулланыла). || *с. мәгъ.* Шул матдәдән әзерләнгән. *Ментол мае.*

МЕ'НТОР: ментор методы — теге яки бу сорт үсемлеккә икенче сорт үсемлек ботагын (үсентесен) ялгап, гибридта ялганган сортның сыйфатларын камилләштерү ысулы. *Мичурин сортларны яхшырту һәм камилләштерү өчен --- ментор методын файдаланган.* Биология.

МЕНЬШЕВИЗМ *и.* Россия социал-демократик эшчеләр партиясендә антимарксистик вак буржуаз оппортунистик агым; реформизмның бер төре.— [*Фәйзи*] *меньшевиклар казанында кайный. Бөтен типография, бөтен союзлары меньшевизм авыруы белән чирлиләр.* Ш. Камал.

МЕНЬШЕВИК *и.* Меньшевизм тарафдары, меньшевистик партия члены. *Бернәрсәсе белән дә күзгә ташланмый торган бу кеше Вакытлы хөкүмәт турында, эсерлар, меньшевиклар турында дөрес, кыю һәм үткен фикерләр әйтте.* И. Гази.

МЕНЬШЕВИКЛА'РЧА *рәв.* Меньшевикларга хас булганча.— *Ничек итеп, Мохтар, икәү бергә торып,* [*Фәйзине*] *бераз рәткә китерә алмыйсың? Нәкъ меньшевикларча уйлый бит.* Ш. Камал.

МЕНЬШЕВИ'СТИК *с.* Меньшевизмга һәм меньшевикларга мөнәсәбәтле булган. *Меньшевистик тайпылыш. Меньшевистик карашлар.*

МЕНЮ *и.* **1.** Иртәнге, көндезге һ. б. ашау вакытына хәзерләнгән ашамлык төрләре. *Ашханәнең менюсы бай булу.*

2. Аш төрләрен күрсәткән исемлек (ашханәдә, ресторанда, кафеда). *Ресторанда меню актарып утырам — күңелемә ошардай аш эзлим.* Т. Миннуллин.

МЕНӘ *а.* **1.** Күз алдында, якында гына булган кемгә яки нәрсәгә, берәр хәл-күренешкә күрсәтү, игътибарны

юнәлдерү өчен кулланыла. *Менә авыл. Яндырылган йортлар урынында, шомлы булып карачкылланып, мичләр, моржалар тырпаеп тораләр.* А. Шамов. *Менә әллә нинди күк күкрәгән, яшен аткан тавышлар ишетелде.* Ш. Мөхәммәдев. || Шул ук мәгънәдә, күрсәтү хәрәкәтенә ияртеп әйтелә. *Сәйфуллa --- элек барып ишек ачты, аннан соң кулы белән күрсәтеп: — Вәли, менә юл, әнә теге ишек! Чык әйдә! Бер минут торма күз алдымда!* Ш. Камал.

2. Эш-хәрәкәтнең әзлеклелеген, күренешләрнең бер-бер артлы алмашынуын күз алдында булып торган кебек итеп сурәтләгәндә кулланыла (тиңдәш кисәкләр алдыннан кабатланып килүе мөмкин). *Менә ярты төн дә узды, таң якынлашты.* Г. Бәширов. *Менә ракеталарның берсе сүнде, менә икенчесе.* И. Гази. *Менә әле генә чәчәкләрне, Өзеп алып, айга кададым, Менә әле генә, айга менеп, Чәчәкләргә көлеп карадым.* Ш. Бабич.

3. Күрсәтү һәм мөнәсәбәтлек алмашлыклары, шулай ук урын, вакыт, сәбәп рәвешләре белән килеп, аларның мәгънәсен ачыклый, көчәйтә. *Еллар үтте, Үләр көннәремдә Очраттым мин аны тагын да: Ләкин охранкада түгел, Менә монда — хөкем залында!* Һ. Такташ. *Безгә менә кичке буш вакытларны файдалы итеп үткәрү турында уйларга кирәк.* Г. Әпсәләмов. || Гомумиләштерүче (йомгак, нәтиҗә ясый торган) сүзләр янында кулланыла.— *Бер корчаңгы бия, ике карт алаша, --- кысыр калган дүрт сарык — менә барлык җан иясе шулар иде.* Г. Ибраһимов. *Менә шул: башка шагыйрьләр тынычлык бер дә бирмиләр, шигырь язганда һәр юлга минем мәгънәне урлыйлар.* Г. Тукай.

4. Логик басым ясап, ассызыклап әйтелгән сүзләр алдыннан килә. *Шушы төштә, менә безнең кебек, Ял итәргә ул да яраткан.* З. Мансур.— *Безнең авыл җирендә ни булсын, менә шәһәрдән кайткан кешелә̆рдән көтәбез инде яңа хәбәрләрне.* М. Әмир. || Әңгәмәдәшнең, бергә сөйләшеп торучының игътибарын җәлеп итү өчен кулланыла.— *Менә күрдегезме, танышлар да булып чыктык, — диде әлеге кеше, елмаеп.* Г. Минский.— *Менә, күр, ике кулымны да күтәрәм.* Д. Аппакова.

5. Тойгылы җөмләләрдә аларның эмоциональ төсмерләрен көчәйтү өчен кулланыла. *Менә кайткач сөйләргә нинди күңелле хәбәр!..* Г. Бәширов. *Әһә... менә кем ул икән явыз карак, Сөт, каймакның башына җитүче, Менә кем ул икән йортымдагы Чүлмәкләрне харап итүче!* Һ. Такташ.

6. „Инде“ сүзенә бәйләнеп килгәндә: хәзер (1 мәгъ.). *Инде менә китүенә дүрт ел узгач, алдан хәбәр итеп тормыйча, көтмәгәндә генә [Сабир] үзе дә кайтып төште.* Э. Еники.— *Бәхет эзләп, аны елатып киттем дә, үзем елыйм инде менә.* М. Фәйзи.

7. *рәв. мәгъ.* Бер үк фигыль белән кабатланып кулланылганда: хәзер, тиз арада. *Хәят матур кашларын җиңел генә күтәренкеләде дә: — Ах, гафу итегез, Николай Иванович, әүвәл менә язам, менә язам дип йөрдем дә, --- аннан соң сезнең адресыгыз алышынган дип ишеттем.* Ф. Әмирхан. || *каб. форм.* **менә-менә.** Хәзер үк, тиз арада. *Менә-менә дошман һөҗүм итә дигән куркыныч астында торган чагында, аңар коллективның язмышы ышанып тапшырыла. Чиксез зур бәхет ич бу!* Ш. Камал. *Менә-менә укулар башланырга тора.* Э. Касыймов.

8. *кис. функ.* Җөмлә ахырында килеп, үзеннән алдагы сүзнең мәгънәсен көчәйтү өчен кулланыла. — *Ах, сердәшем, — диде Бану, — шундый сагындым, шундый сагындым менә.* А. Шамов.— [*Киндер тукмаклау*] *тавышлары шул кадәр матур булып ишетелә̆дер иде. Һич сөйләп тә бетергесез менә!* Г. Камал.

9. *кис. функ.* „Бит“, „ич“, „инде“ кебек кисәкчәләр белән килеп, кушма кисәкчәләр ясый, сөйләмнең эмоциональлеген, сәнгатьлелеген арттыра. *Менә бит ул ничек, дуслар, хат ташучы бәласе!* М. Җәлил.

10. *күч. сөйл. к.* менә дигән.— *Сөнгать абый бит ул, дпрәүләр түгел. Егете — менә!* М. Фәйзи.

11. *күч. сөйл.* Кыйнаганда, сукканда, үч итеп берәр нәрсә эшләгәндә әйтелә.— *Нәгъләт төшкерләре, югалыгыз күземнән! Менә, менә, менә, күп сугышып йөрсәгез.* Ә. Фәйзи.

◇ **Менә генә** — 1) күз алдында, каршыда, якында гына. *Хәзер менә ул аның каршысында... Менә генә ул.* Г. Бәширов; 2) әле генә, хәзер генә. **Менә дигән**— 1) бик яхшы. *Хәлимнең --- аякларында менә дигән солдат итекләре иде.* Г. Гобәй.— *Син чибәр, синең өс-башың да менә дигән булырга тиеш.* Ә. Еники; 2) бик шәп, бик уңган.— *Галиябану бик бәхетле кыз икән, менә дигән егеткә бара.* М. Фәйзи.— [*Нәфисәнең*] *сеңелесе дә менә дигән, тик әз генә басынкырак.* Ф. Бурнаш. **Менә мин сине (сезне)** — янап, куркытып әйтелә. *Сания, Маратны яклап, Илдарга ташланды.— Нигә тиясең син аңа, ә? Әнигә әйтим әле менә мин сине!* Г. Гобәй. **Менә ничек!** — гажәпләнүне белдерә.— *Ах, менә ничек! Серкәбез су күтәрми, диген.* Р. Ишморат. **Менә син** — кара инде (гажәпләнүне белдерә).— *Менә син, әй!.. Нинди җаваплы эшкә шундый юньсез нәмәрсәне утыртып куйганнар бит!* Г. Гобәй. **Менә сиңа** — 1) тиешле җәзаңны ал. [*Нәгыйм*] *эшергечнең чукмарын Нокта Вәлинең түбәсенә кундырды: — Менә сиңа! Безнең комсомолларга кул тидергән өчен! — диде.* Ш. Камал; 2) кимсетүле караш, кире мөнәсәбәтне белдергәндә әйтелә. — *Менә сиңа оялчан кеше!* Һ. Такташ; 3) үтәлмичә калган яки бөтенләй башкача, көтелмәгәнчә килеп чыккан эш-хәл турында әйтелә. **Менә (сиңа) кирәк булса** — көтелмәгән, гажәпләндерерлек бер хәл уңае белән туган хисне белдерү өчен әйтелә.— *Әтиләр мине Исмәгыйльгә бирдек дип белгәннәр. Мин моны ишеткәч, аптырап калып, нишләгәнемне дә белмәдем.— Менә кирәк булса! Соң ничек булып бетте?* М. Фәйзи.— *Менә сиңа кирәк булса пионерка, ялындырып тора.* А. Алиш. **Менә (сиңа) мә!** — *к.* менә сиңа кирәк булса. [*Шәрәф:*] *Бу ни соң? --- Кызлар хаты! Менә мә! Кызлар да хат яза башлады.* М. Фәйзи. **Менә тагы(н)** — әңгәмәдәшенең фикеренә гажәпләнүле һәм килешмәүчән мөнәсәбәт белдерә. — *Кисмәкләр нәрсәгә? — Менә тагы!.. Пожар сүндерергә.* Г. Гобәй.— *Менә тагын, шулай булмыйча, үз улларыбыз лабаса.* Г. Бәширов. **Менә шул-шул** — әңгәмәдәшенең фикере белән килешүне белдерә. — *Борын ат алырдан алда йөгәнен әзерләп куярга куша торганнар иде. — Менә шул-шул! — диде Мостафин, тизрәк килешеп.* Ә. Еники.

МЕНҮ *ф.* **1.** Югарыга таба хәрәкәт итү, күтәрелү. *Казаннан Мәскәү күренә, Менсәң биек тауларга.* Ш. Маннур. *Габдулла --- баскычтан ничек менгәнен һәм ишекне ничек ачканын хәтерләми өйгә керә.* Ә. Фәйзи. *Астан, йөкләр причалыннан, берөзлексез диярлек машиналар менеп тора.* Э. Касыймов. || Үрмәләп, нәрсәләргә дә булса тотынып, биеклеккә, берәр нәрсәнең югары башына күтәрелү. *Колгага менү.* □ *Мин, алардан качып, карама башына мендем дә күке булып кычкырдым.* М. Әмир. || Гадәттә „басу“, „утыру“ сүзләре белән һәм алардан башка: югарырак урынга (сәкегә, урындыкка, сәхнәгә) күтәрелү.— *Безнең мех турында трибунага менеп сөйләү генә түгел, мактап җырларга да була.* Р. Ишморат. *Кечкенә Шәфыйк, этисенең тез өсләренә менеп утырып, аның орденнары белән уйнарга ярата.* Г. Гали. || Кая да булса бару өчен машинага, пароходка, вагонга

утыру, кереп урнашу турында. *Вагоннарга менү өчен хәл кирәк, --- кешеләрне этеп-төртеп менәргә кирәк. Хәлимдә анлык көч юк иде.* Г. Гобәй. *Маликның кече улы йөк өстенә әре генә менеп утырды.* И. Гази. || Очып, югарыга, һавага күтәрелү. *Ай югары, ай югары, Айга менәсем килә.* Җыр. *Бер менеп, тагын уктай төшеп, Балык аулый җитез акчарлак.* Ш. Мөдәррис. || Агымга каршы хәрәкәт итү, йөзү. *Түбән яктан зур бер пароход менеп килә.* Г. Бәширов.

2. Югарырак җиргә, кашлакта урнашкан берәр урынга бару, килү. — *Без бүген таң белән, меңләгән кеше җыелып, --- Арча кырына мендек.* М. Гали. *Гарәфи абзый белән сөйләшкәннән соң, Газинур ындырга менде.* Г. Әпсәләмов. || Түбәннән югары катка күтәрелеп берәр кеше янына керү.— *Син миннән курыкма. --- Мин синең яныңа сөйләшергә мендем.* Г. Коләхметов.

3. Өске якка үтеп керү, таралу (төтен, ис, пар һ. б. турында). *Ашханәдәге май исе белән төтен мәдрәсәгә менгән иде.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Югарыга ишетелү, таралу (тавыш, җыр турында). *Күкләргә менсен җырларың, Минем гүзәл Казаным.* Ш. Маннур. || Тән буенча таралып күтәрелү (берәр төрле авыру турында). *Бу чәнчү күкрәгемә, кулбашларыма менде.* Г. Ибраһимов.

4. Атлану, атланып утыру. *Акбүз юргаларга менеп, илләрне гизәр идем.* М. Фәйзи. *Мендем мин атка, Кулымда кылыч.* Ф. Кәрим.

5. Арту, җәелү, тирәнәю; күтәрелү (су, дулкыннар турында). *Су туктаусыз арта, бераздан тезгә менде, аякларны читкә сөйри башлады.* Г. Бәширов. *Дулкыннар ярга йөгереп менәләр дә, вак ташларны өстерәп, шаулап, кире төшеп китәләр.* И. Гази.

6. Җылылык, эсселек арту, көчәю турында. *Хәтирә [докторга] әнисенең температурасы язылган кәгазьне сузды. — Уһу, 39! Кая, карап карыйк әле, хәзер ничәгә менде икән?* Г. Минский.

7. Өскә калку (сыеклык эчендә батмый торган әйберләр турында).

8. *күч.* Властька, югарырак иҗтимагый дәрәҗәгә, яхшы эш урынына ирешү. *Алар икәве, бигрәк тә генерал Корнилов, власть башына менү хыялы белән шашынып йөргәннәр.* И. Гази. *Язу-сызу белмәгән Сәфәргалинең шул дәрәҗәгә менүенә карт та, карчык та бик шатланалар.* М. Гафури. || Югары сыйфатка ия булу, ирешү турында.— *Бу нәрсә бит чын сәнгать әсәрләре дәрәҗәсенә менеп җитмәгән, бары гади бер панорама гына.* Г. Бәширов.

9. Арту, күтәрелү (эш хакы, бәяләр турында). — *Әйбер бәяләре котырынып үсә. Бер көн бер хак, икенче көн инде аның ике бәясенә менгән.* Ш. Камал.

10. *күч.* Җитү, үсү (яшь турында).— *Белем ягы да бик сай инде минем, яшем дә алты дистәнең өске ягына менеп бара.* Г. Бәширов.

11. *күч.* „Сәхнәгә“ сүзе белән килгәндә: тамашачылар алдына чыгу (җырлау, бию һ. б. өчен). [*Фатыйма ханымның*] *бу тавыш, бу көйләрдән хәбәрсезлек вә бу акценты белән сәхнәгә менүе бик урынсыз.* Ф. Әмирхан.

Менеп бару — югарыга таба хәрәкәт итеп ераклашу хәлендә булу. *Урамда арба шыгырдаган тавыш ишетелде, карасам: көлтә төялган аллы-артлы ике арба югары таба менеп баралар.* Г. Ибраһимов. **Менеп килү** — югарыга таба хәрәкәт итеп якынлашу хәлендә булу. *Нокта төсле нәни кызыл бөҗәк Менеп килә чәчәк очына.* Ш. Мөдәррис.— *Аһа, иптәшләр, тәгә оч егетләре — ак чабата, ак оеклар менеп киләләр.* Г. Камал. **Менеп китү** — кая да булса югарыга таба, үрге якка юнәлү. *Ял көне иде. Гармонь алдык та без Менеп киттек таулар өстенә.* Ш. Маннур. **Менеп төшү** — 1) кая да булса менеп кире төшү. [*Әхмәт*] *залны да йөреп чыкты, югары катка, балконга да менеп төште. Рабига юк иде.* Г. Минский; 2) кая да булса барып кайту. *Югары очка менеп төшү;* 3) *күч. гади с.* сугу, кыйнау. *Ул, үзенең буе җитмәслегенең күренеп торуына карамастан, „фәлән агайның авызына менеп төштем әле, фәлән кешенең баш түбәсен төйдем әле“, — дип --- мактана иде.* Ф. Әмирхан. **Менеп җитү** — билгеләнгән урынга яки билгеле бер чиккә кадәр күтәрелү, менү. *Таң сызылганчы без, Миус суын кичеп, кыялар түбәсенә менеп җитәргә һәм шуннан, сигнал буенча, атакага ташланырга тиешбез.* И. Гази. **Менү аты** — атланып йөрүгә генә тотыла торган ат. *Тарханнар һәм илчеләр алардан олау һәм менү атлары алмасыннар.* Каз. утл.

МЕ'РГЕЛЬ *и.* Кызыл балчыклы һәм известьташлы утырма тау токымы. *Тизрәк, тизрәк бу күңелне тырный торган мергель бетсен иде. Ләкин мергель катлавы тиз генә җиңелергә уйламады ахры.* Р. Ильяс.

МЕРЕ'ЖКА *и. махс.* Тукымада аркау яисә буй җепләрен суырып алган урынга эшләнгән челтәр. *Мережка ясау өчен тукыманың берничә җебен суырып алалар.* Йорт эшләре.

МЕРЕ'ЖКАЛАУ *ф. махс.* Челтәрләп-юллап чигү. *Төсле җеп белән мережкалау. Әйбернең читен мережкалау.*

МЕРИДИАН *и. геогр.* Җир шарының полюслары аша үтә һәм экваторны туры почмак ясап кисә торган уйланма йомык сызык. *Дөньяның бөтен меридианнары аның өчен шушында [Күктәү авылында] кисешәләр.* А. Гыйләҗев. *Тайга белән сахра кул биреште, Җансыз яткан дала җанланды. Төрксиб дигән данлы төен белән Меридианнар бергә ялганды.* Э. Ерикәй.

МЕРИДИОНАЛЬ *с. геогр., астр.* Меридиан юнәлешендә булган, меридиан буенча сузылган. *Меридиональ сызык. Меридиональ яссылык.*

МЕРИНОС *и.* **1.** Йомшак һәм нечкә ак йонлы сарык токымы.

2. Шундый сарыкның йоны яки шул йоннан эшкәртелгән тукыма. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан эшләнгән. *Меринос шәл. Меринос тукыма.*

МЕРКАНТИЛИЗМ *и.* **1.** *полит.* XV—XVIII йөзләрдә Көнбатыш Европа сәүдә буржуазиясенең, имеш, илнең байлыгы җитештерүне үстерүгә түгел, ә тышкы сәүдәдә актив баланс булдыруга һәм акча капиталы туплауга бәйле, дигән экономик өйрәтмәсе һәм политикасы.

2. *күч. кит.* Исәп-хисапта вакчыллык, үз файдаң, баю өчен генә тырышучанлык.

МЕРКАНТИЛИСТ *и.* Меркантилизм тарафдары. *Меркантилистлар феодализм эчендә үсеп чыккан тышкы сәүдәне үстерү, колониаль талаулар, сәүдә сугышлары һәм артта калган халыкларны коллыкка төшерү юлы белән алтын һәм көмеш формасында байлык тупларга омтылган буржуазия интересларын гәүдәләндерәләр.* Политэкономия.

МЕРКАНТИЛИ'СТИК *и.* Меркантилизмга (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле. *Меркантилистик политика.*

МЕРКАНТИЛЬ *с.* Меркантилизмга (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле. *Меркантиль система.*

МЕСКЕН *с.* **1.** Бәхет, шатлыктан мәхрүм булган; бәхетсез, бичара. *Мескен ана йоклый алмый Төннәр буе утыра; Хәсрәтенә түзә алмыйча, Бер утыра, бер тора.* Ә. Ерикәй. *Эч яна, тормыш тигезсезлекләрен уйлап яна, Моңлы мескен бәндәләрнең моңнарын сөйләп яна.* Ш. Бабич. || Газапланулы, кайгылы рухи халәтне чагылдыра торган; ялынулы-ялварулы

(караш, тавыш турында). *Илсөяр Матвей Ивановичның мескен күзләренә, аннан бармагындагы йөзек кашына карады.* Г. Гобәй. *Кинәт: — Хәер-сәдакаларыгызны рәхим итегезче! — дигән мескен тавыш ишетелде.* А. Әхмәт.

2. Берәр төрле бәлагә, бәхетсезлеккә дучар булган; бик зур кайгы кичерүче. *Хисами, бу мескен картның җаны калмавына тәмам ышангач, кесәсеннән теге көнне Хәйри онытып калдырган пәкене чыгарды.* Г. Минский. *Мескен, бичара хатын, иреннән тәмам гаҗиз булгач, аерыла алмам микән, дип, хәзрәт янына бара.* Г. Камал. || *и. мәгъ.* Бәхетсезлеккә дучар булган, бик зур кайгы яки мохтаҗлык кичерүче кеше.— *Мескеннәрне, үлеп бара торган кешеләрне генә юаталар, мин мескен түгел.* Р. Ишморат. || *гадәттә ирк. форм.* Кызгану һәм теләктәшлек хисе уята торган шундый хәлдәге кеше.— *Бәкегә төшкән, мескенкәй, ике көннән соң гына табып алдылар.* М. Гафури. *Соңгы сүзе өтеп, каберемә кызыл йолдыз утыртырсың, диде дә беләгемә ятып җан бирде, мескенкәем.* М. Фәйзи.

3. Тышкы кыяфәте, күренеше белән кызгану хисе уята торган.— *Хәтта мескен Җәләйне дә [солдатка] алдылар.— Сыңар күзе белән ме? — Әйе, бер күзе белән.* Т. Гыйззәт. *Мескен арык вә кечкенә ат, сыртына чыбыркы төшкән саен, арт санын азрак сикертә вә койрыгын ике якка чайкап ала.* Ш. Камал. || Ярлылык, мохтаҗлык яки берәр фаҗига, афәт кичерү билгесен күрсәтеп торган (җансыз әйберләр турында). *[Гәрәй мирзаның] чибәрләп салынган зур өйләре — авылның җиргә сеңеп, юк булырга торган кебек мескен вә аяныч биналары уртасында, патша сарайлары шикелле, үзләренә тиң тапмыйча, башларын күккә күтәреп утыралар.* Г. Ибраһимов.

Мескен бүрек — сырып эшләнгән кырпусыз бүрек. *Татарлыгым беленмәсен дип, киядер идем кара эшләпә; Хәзер мескен бүрек тә юк — менә заманасы нишләтә!* Ш. Мөхәммәдев.

МЕСКЕНЛЕК *и.* Мескен булу хәле. *Мескенлек тойгысы кичерү.* □ *Бары Федоровны күргәч кенә аның йөзенә элекке ясалма мескенлек йөгерде.* А. Расих.

МЕСКЕНЛӘНҮ *ф.* Мескен кыяфәткә керү. *Нияҗять, көткән кешесеннән җавап килде. Мескенләнә язып гафу үтенгән.* Э. Касыймов. *Туры ат бик кечкенәләнде, мескенләнде.* М. Гафури.

МЕСКЕННӘ'РЧӘ *рәв.* Мескен кешеләргә хас булганча; мескен кыяфәт белән. *Мескеннәрчә, тагын оялмыйча, Коллык богауларын киямсез?* Һ. Такташ.

МЕСКЕНЧЕК, МЕСКЕНЧӘК *и.* Кызганып, иркәләп әндәшү сүзе. *Мескенчегем, син дә хәзер, минем бервакыттагы кебек, әллә нинди хыяллар белән әвәрә була торгансыңдыр.* Ш. Камал. *[Энә карагы] пыр-пыр оча, ул да, мескенчәгем, чәчәк балын авыз иткән була.* А. Алиш.

МЕС-МЕС: мес-мес итү *диал.* — йоклау, йоклап китү.

МЕСНӘҮ *ф. диал.* Йоклау. *Кәрам аның борын сызгырта-сызгырта месәвенә карап алды.* Каз. утл.

МЕСТКОМ *и.* Профсоюз оешмасының җирле (урындагы) комитеты. *Местком утырышы.* □ *Шуның өчен почта эше Ударнигы Булатны Дирекция, местком шушы Баян белән бүләкли.* М. Җәлил.

МЕТАЛЛ *и.* Махсус ялтыравык, чүкелүчәнлек, җылылык һәм электр үткәрүчәнлек сыйфатларына ия булган гади химик матдә (яки коелма). *Төсле металлар. Кара металлар. Җиңел металлар. Металл кою.* □ *— Син җыйган тимер-томырлар заводларга китә, эретелә, металл була.* А. Әхмәт. *Урмандагы ак каеннар өчен, Уралдагы металл өчен без Якалаштык явыз үлем белән, Какшамады безнең көчебез.* З. Мансур. || *с. мәгъ.* Металлдан эшләнгән. *Металл кием. Металл акча системасы. Металл конструкция.*

МЕТАЛЛАШТЫРУ *ф.* Берәр материалга, ясалган әйбергә, нинди дә булса үзлек бирү өчен, металл йөгертү. *Тукыманы вакуумда металлаштыру. Металлаштырылган магний.*

МЕТАЛЛОГРА'ФИК *с.* Металлографиягә мөнәсәбәте булган. *Металлографик тикшеренүләр.*

МЕТАЛЛОГРА'ФИЯ *и.* Металларның һәм эретмәләрнең эчке төзелешен, физик үзенчәлекләрен өйрәнә торган фән.

МЕТАЛЛО'ИД *и. хим.* Металларга керми торган химик элементның (мәсәлән, күкерт, фосфор һ. б.) искергән атамасы. || *с. мәгъ.* Металлоидка мөнәсәбәте булган. *Металлоид элементлар.*

МЕТАЛЛОМ *и. сөйл.* Металл ватыклары, тимертомыр.— *Әйдәгез металлом җыябыз. Күрше мәктәптә өч тонна җыеп тапшырганнар.* Н. Дәүли.

МЕТАЛЛОФОН *и.* Металл пластинкаларны билгеле бер тәртиптә тезеп эшләнгән һәм агач чүкечләр белән сугып уйный торган музыка коралы.

МЕТАЛЛУ'РГ *и.* Металлургия белгече.

МЕТАЛЛУ'РГИЯ *и.* Рудалардан металл алу һәм металларны башлангыч эшкәртү белән шөгыльләнә торган авыр промышленность тармагы. *Металлургия институты. Урал — металлургия базасы.*

МЕТАЛЛЧЫ *и.* Металлургия промышленносте эшчесе. *Көтүче малае да түгел Хисмәт. - - - Металлчы да түгел, тиреченең дә.* Ш. Маннур.

МЕТАМОРФИЗМ *и. геол.* Физик һәм химик сәбәпләр аркасында тау токымнарының төзелешләре һәм составлары үзгәрү күренеше. *Тау токымнары метаморфизмы.*

МЕТАМОРФОЗ, МЕТАМОРФО'ЗА *и.* **1.** *кит.* Бер форманың нинди дә булса икенче формага әверелүе.

2. *биол.* Тарихи үсеш процессында үсемлек органнарының формасы һәм төзелеше яки бер үсеш стадиясеннән икенчесенә күчкәндә хайваннарның тышкы кыяфәте һәм тереклек итү рәвеше үзгәрү күренеше. *Ефәк корты метаморфозы. Үсемлекләрнең яфрак һәм тамыр метаморфозасы.*

3. *кит.* Кемдә яки нәрсәдә дә булса кискен үзгәреш. *Мондый романтиканың метаморфозасы бик гади һәм җиңел аңлашыла: аның өстендә инде яңа чынбарлыкның чаткысы уйный.* Г. Халит. *Менә ничек көтелмәгән метаморфоза! Ничек соң бу? Әле генә Шәйхзадә иде, хәзер синең алдыңда чынлап та кыямәт хәлләрен үз күзе белән күргән бер агай тора.* Н. Исәнбәт.

МЕТАН *и.* Углерод белән водород кушылмасыннан торган төссез газ. *Метан ятмалары.* □ *Метан һавадан ике тапкыр чамасы җиңелрәк.* Химия.

МЕТАСТАЗ *и. мед.* Кан агышы белән тәндәге авыруның бер урыннан икенче урынга күчү күренеше. *Рак метастазы.*

МЕТАТЕ'ЗА *и. лингв.* Сүздәге ике авазның яки иҗекнең урыннарын алмаштырып әйтү күренеше (мәсәлән: *абзар — азбар, кырмыска — кымырыска).*

МЕТАТЕ'ЗАЛАШУ *ф.* Метатеза күренеше кичерү. *Сүздәге янәшә тартыкларның метатезалашуы.*

МЕТАФИ'ЗИК I *с.* **1.** Метафизикага (1 мәгъ.) нигезләнгән. *Метафизик материализм.*

2. *күч.* Абстракт, бик томанлы, аз аңлаешлы.

МЕТАФИ'ЗИК II *и.* **1.** Метафизик I (1 мәгъ.) философия тарафдары. *Метафизиклар дөньядагы, табигатьтәге әйберләрнең һәм күренешләрнең үзара бәйләнешен, бер-беренә тәэсир итүен танымыйлар,*

һәрнәрсәне үзенә аерым яши дип карыйлар. М. Абдрахманов.

2. *иск.* Тәҗрибә рамкаларыннан читкә чыга торган мәсьәләләр белән шөгыльләнүче философ.

3. *күч.* Абстракт фикер йөртү белән мавыгучан кеше турында.

МЕТАФИ'ЗИКА *и. филос.* **1.** Диалектикага капма-каршы буларак, күренешләрне бер-берсенә бәйсез, каршылыксыз, үсешсез-үзгәрешсез, хәрәкәтсез дип карый торган танып белү методы. [*Эстетиканың*] *юлы — физикадагы кебек үк, объективизм, чөнки һәртөрле метафизика аңа яттыр.* Г. Ибраһимов.

2. Марксизмга кадәрге идеалистик философиядә: философиянең тәҗрибә ителә алмый торган (алла, рух, ихтыяр иреге һ. б. ш.) мәсьәләләрне аңлата торган бүлеге.

3. *күч.* Абстракт, мәгънәсез фикерләү, акыл сату турында; артык гомуми, аз аңлаешлы, томанлы нәрсә (мәсәлән, фикер).

МЕТА'ФОРА *и. әд.* Сүзне яки тәгъбирне күчмә мәгънәдә куллану (охшашлык, чагыштыру, аналогия нигезендә).— *Сезнең талантлы шагыйрь булуыгыз үткен сөйләшүегездән, халыкчан метафора һәм аллегорияләрегездән үк күренеп тора.* Ш. Маннур.

МЕТА'ФОРАЛАШТЫРУ *ф. сир.* Күчмә мәгънәдә бирү, читләтеп, киная белән әйтү. *Шагыйрь яз образын Бөек Октябрь вакыйгалары аша метафоралаштырды, нәтиҗәдә язның һәрбер күренешенә --- иҗтимагый-политик һәм сугышчан мәгънә бирде.* Х. Госман.

МЕТАФО'РИК *с.* **1.** Күчмә, читләтеп әйтелгән. *Метафорик сүз кулланыш.*

2. Метафораларга бай булган. *Метафорик стиль.*

МЕТЕО- Кушма сүзләрдә „метеорологик“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **метеобелешмә, метеограмма, метеобудка, метеостанция.**

МЕТЕОР *и. астр.* Җир атмосферасында бик тиз хәрәкәт итүче уттай кызган космик җисем; атылган йолдыз. *Мөстәкыйль идарәгә көйләнгән ракета алга ыргылды, метеорлар күче арасында буш урын эзләп, юл табарга теләп боргаланды.* А. Тимергалин. *Кеше гомере метеор кебек, Ялтырый да тынып кала.* Г. Латыйп. || *с. мәгъ. к.* метеорик. *Метеор матдәләр.*

МЕТЕО'РИК *с. астр.* Метеорга мөнәсәбәте булган. *Метеорик күренеш.*

МЕТЕОРИ'Т *и. астр.* Планетаара бушлыктан бөтенләй эреп яки тузанга әйләнеп бетмичә җиргә төшкән метеорик җисем. *Мәчетнең михрабына Кәгъбәдәге кара метеоритның бер кисәген салып калдырганнар.* Сов. әд. || *с. мәгъ.* Метеоритка мөнәсәбәте булган. *Метеорит кисәкләр.*

МЕТЕОРО'ГРАФ *и.* Атмосфераның югары катлауларында һаваның температурасын, басымын, дымлылыгын автомат рәвештә язып бара торган прибор.

МЕТЕОРО'ЛОГ *и.* Метеорология белгече. *Әби Полярный Круг станциясенә, кияүдәге кызы янына бара икән. Кызы анда метеоролог булып эшли.* Г. Әпсәләмов.

МЕТЕОРОЛО'ГИК *с.* Метеорологиягә мөнәсәбәте булган. *Метеорологик күзәтүләр. Метеорологик станция.*

МЕТЕОРОЛО'ГИЯ *и.* **1.** Җир атмосферасы, аның төзелеше, үзенчәлекләре һәм анда бара торган физик процесслар турындагы фән.

2. Һава торышы һәм аны алдан әйтеп бирү турындагы өйрәтмә. *Метеорология буенча халык тәҗрибәсе. Метеорология күзәтүләре.*

МЕТЕОСТА'НЦИЯ *и.* Метеорологик станция. *Һава торышы турында җирле метеостанция мәгълүматлары.*

МЕТЕР *с. диал.* Вакчыл. *Юк кына нәрсә өчен дә атна буе сукранып йөрүче метер хәзрәт* [*абыстайның*] *башын ашаячак.* Г. Мөхәммәтшин.

МЕТИЛ *и. хим.* Бик күп органик кушылмалар составына кереп, бер атом углеродтан һәм өч атом водородтан торган группа. || *с. мәгъ.* Составында метил булган. *Метил эфиры. Метил спирты.*

МЕТИС *и.* **1.** *биол.* Төрле токым кушылуыннан килеп чыккан үсемлек яки хайван.

2. Төрле раса кешеләре өйләнешүдән туган буын. || Индеецлар белән европеоид раса кешеләре никахланудан туган буын.

МЕТИСЛАШТЫРУ *ф.* Токымын яки сортын яхшырту өчен төрле токым хайваннарны яки төрле сорт үсемлекләрне җенси кушылдыру.

МЕТЛАК: метлак плита — керамик плита.

МЕТМЕЛДӘТҮ *ф. сөйл.* Иреннәрне сүз әйтергә яки еларга әзерләнгәндәге кебек кыймылдатып тору. *Кеше сүзен тыңлаганда ул ни өчендер авызын метмелдәтеп тора.* М. Мәһдиев.

МЕТ-МЕТ *рәв.* Бик еш хәрәкәтләндереп, кыймылдатып (күзләр, иреннәр турында). *Камалиның метмет йомылган күзләренә әйтерсең лә кояш чаткысы чәчрәп төште.* К. Нәҗми.

МЕ'ТОД *и.* **1.** Табигать күренешләрен һәм иҗтимагый тормышны танып белү, тикшерү ысулы. *Диалектик метод. Чагыштыру методы. Эксперименталь метод.*

2. Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсендә кулланыла торган алым, алымнар системасы. *Социалистик эш методы. Язучының иҗат методы. Укыту методы. Революцион көрәш методы.* □ *Ул миңа җирне тизләтелгән метод белән бораулау турында киңәшләр бирде.* А. Әхмәт.

МЕТО'ДИК *с.* **1.** Методикага мөнәсәбәте булган. *Методик кабинет.* □ *Д уен, ул чорда аның үзе өчен, бернинди тәҗрибәсез, методик көчсез яшь укытучы өчен, берни белән алыштыргысыз тәрбия чарасы булган икән.* Г. Ахунов. *Безнең методик киңәшмә утырышы иде.* Э. Касыймов.

2. Билгеле бер максат белән аңлы һәм эзлекле рәвештә башкарыла торган. *Дошман әллә ни активлык күрсәтми, безнең сафларны минометлардан һәм артиллериядән методик рәвештә утка тоту белән генә чикләнә иде.* Каз утл. *Методик сайланыш — булган сортларны һәм токымнарны яхшырту яки яңаларын булдыру максаты белән, кеше тарафыннан аңлы рәвештә эшләнә торган сайлау ул.* Биология.

МЕТО'ДИКА *и.* **1.** Берәр нәрсәне тормышка ашыруда кулланыла торган алымнар, методлар җыелмасы. *Халык авыз иҗатын өйрәнү методикасы. Татар телен укыту методикасы.* □ *Рәхим, үзенең сынаулар үткәру методикасын һәм беренче этапка куйган төп максатын сөйләгәннән соң, аркасының һәм маңгаеның тирләп чыгуын тойды.* А. Расих.

2. Теге яки бу фәнне укыту методы турындагы өйрәтмә. *Башлангыч классларда укыту методикасы.*

МЕТОДИСТ *и.* Нинди дә булса предметны укыту методикасы буенча белгеч. *Үзен яхшы белгеч, методист-педагог итеп таныта алган профессор Долговка Солтан тиз ияләште.* Г. Кутуй.

МЕТОДОЛО'ГИК *с.* Методологиягә мөнәсәбәте булган. *Методологик күрсәтмәләр.* □ [*Татар әдәбияты тарихы турында*] *төрлечә фикер йөртүләрнең сәбәбе — әдәбият тарихының ныклы эшләнмәгән булуында. Бигрәк тә бу тарихның методологик проблемалары җитәрлек тирән яктыртылмаган.* Х. Госман.

МЕТОДОЛО'ГИЯ *и. кит.* Гомумән фәнни метод һәм аерым фәннәр методы турында өйрәтмә. *Марксистик методология.* □ *Галимҗан Ибраһимовның гомуми әдәбият методологиясендәге фикерләренә анализ ясауга тукталмасак та, монда бу мәсьәлә белән бәйләнгән бер-ике ноктага тукталып үтәргә кирәк.* Г. Гали. || *сир. ирон.* Нинди дә булса бер эштә кулланыла торган алым,ysул. *Әлеге ике сәүдәгәрнең мактануларына чыдар хәл калмады. Аларның мактануларында аерым бер методология дә бар иде. Алар чагыштыру методын кулланып мактандылар.* Г. Газиз.

МЕТОНИ'МИК *с.* Метонимияне эченә алган. *Метонимик тәгъбир. Метонимик сүзкулланыш.*

МЕТОНИ'МИЯ *и. әд.* Бер күренешне, предметны безнең аңыбызда аңа тыгыз бәйләнештә булган икенче нәрсә исеме белән белдерү (мәсәлән: „залдагы халык тынлый“ урынына „зал тынлый“); образлы итеп кулланылган шундый сүз яки тәгъбир.

МЕТР I *и.* **1.** Йөз сантиметрга тигез озынлык үлчәве берәмлеге. *Юлдан дүрт йөз метр чамасы гына читтә, тигез кыр уртасында, кечкенә ап-ак каенлык күренә иде.* Ә. Еники. *Кандыр суы ел әйләнәсендә дүрт метрга күтәреләчәк, тирәнәячәк.* К. Тинчурин.

2. Шундый озынлыкта сантиметр бүлемнәре төшерелгән линейка. *Маннур, --- кесәсеннән җыелмалы метр чыгарып, бидоннарның озынлыгын, төбенең киңлеген, тоткасының биеклеген үлчәп --- язып алды.* М. Хәсәнов.

МЕТР II *и.* **1.** *әд.* Шигырь төзелешендә — шигъри үлчәм, стопа. *„Аруз, төрки телләрдәге поэзиядә гасырларча хакимлек итүче метр буларак, соңыннан бу телләрдән тизлек белән төшеп калды“.* Х. Госман.

2. *муз.* Такттагы көчле һәм көчсез өлешләрнең чиратлашуында бертигезлек.

-МЕТР Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган икенче кисәк: 1) сүзнең беренче кисәгендә күрсәтелгән озынлыкта, мәсәлән: **километр, сантиметр, миллиметр;** 2) сүзнең беренче кисәгендә белдерелгәнне үлчәү өчен кулланыла торган прибор, мәсәлән: **вольтметр, динамометр, термометр, арифмометр.**

МЕТРАЖ *и.* **1.** Нәрсәнең дә булса метр белән үлчәнгән озынлыгы. *Кинолента метражы. Тукыманың метражы.*

2. Берәр нәрсәнең (мәсәлән, бүлмәнең) квадрат метрлар белән үлчәнгән мәйданы.

МЕТРАНПАЖ *и. махс.* Типографиядә җыелган наборны биткә салучы эшче. *Боларның арасында метранпаж Шәмси Гайнетдинов дигәннәре Җамалига күптән таныш иде.* Г. Ибраһимов. *Метранпаж Сибгать абзый наборны битләргә сала башлаган иде.* И. Гази.

МЕ'ТРИК I: **метрик система** — үлчәү берәмлеге итеп метр алынган халыкара үлчәү системасы.

МЕ'ТРИК II *с.* Метрикага (I) мөнәсәбәте булган. *Поэзия жанры үзенең метрик оешканлыгы, рифмалардан торган авазлар ярашуының системасы һәм ритмик яңгырашы белән музыкага ныграк якын.* Ж. Фәйзи.

Метрик шигырь төзелеше — озын һәм кыска иҗекләрнең чиратлашуына нигезләнгән шигырь төзелеше.

МЕ'ТРИКА I *и. әд.* Шигырь үлчәве турындагы өйрәтмә. *Гарәп-фарсы метрикасына корылган көйләп укыла торган шигырьләр урынына интонацион сөйләүгә нигезләнгән шигырьләр --- барлыкка килә.* Ә. Исхак. || Шигырь үлчәве ноктасыннан караганда шигырьнең төзелеше. || Шигырь үлчәүләре җыелмасы.

МЕ'ТРИКА II *и.* **1.** Туу турында метрика дәфтәреннән (кенәгәсеннән) алынган күчермә; туу турында таныклык. [*Ул*] *баланың метрикасы белән кыйммәтле әйберләрен, өстәлдән учына себереп төшереп, Гөлсем апага бирде.* Г. Гобәй.— *Кара әле, энем, мелла Җәләлетдин, метрикасы авылда булгач, кем аны* [*кызның яшен*] *тикшереп торыр дисең.* Ш. Камал.

2. *иск. к.* метрика дәфтәре.— *Сиңа әйтәм, — диде Галимулла, — без аны яңа елсыз метрикага кертми торырбыз, бер елга булса да, солдатка соңрак алыныр.* И. Гази.

Метрика дәфтәре (кенәгәсе) — туу, үлү, өйләнешү актларын теркәп бара торган төп кенәгә. *Мулла, --- букчасын тәрәзә төбенә алып, күн тышлы метрика дәфтәре белән каләм-карасын чыгарып куйды.* Г. Ибраһимов. **Метрика кәгазе** — *к.* метрика II (1 мәгъ.). *Хәйбуш яшь чакта авыллары янган, метрика кәгазьләре сакланмаган.* Г. Әпсәләмов.

МЕ'ТРЛАП *рәв.* **1.** Метр озынлыгында итеп, метр үлчәме белән. *Метрлап сату.* □ — [*Нефтьне*] *аны литрлап үлчиләр түгелме соң, син метрлап үлчисең икән.* А. Әхмәт. || *күч.* Бик күп, күпләп. *Шулай инде ул, Фатих туган, безнең эш: баштан сыйпау миллиметрлап булса, тиргәве метрлап элгә.* Ф. Хөсни.

2. Микъдар саннарыннан соң килгәндә: метр чамасы. *Моннан бер йөз метрлап уңдарак разведчиклар кыя битендә чытырман куаклык эзләп тапканнар.* И. Гази.

МЕ'ТРЛЫ *с.* Бер метр озынлыгындагы яки бер метр киңлегендәге. *Хәлимнәр --- эшелонга утын төяп торган кешеләр янына килеп чыктылар. Аларның кулларында метрлы юан агачлар уракчылар кулындагы көлтәләр шикелле җиңел йөрде.* Г. Гобәй.

МЕТРО *и. к.* метрополитен. *Метро поезды.* □ *Синең белән моннан ун ел элек Метро төзегән чакта күрештек.* Ә. Ерикәй.

МЕТРО'ВКА *и. сөйл.* **1.** Җыелмалы метр.

2. „А“ хәрефенә охшатып эшләнгән җир үлчәү таягы (гадәттә ике метр озынлыгында була). *Тимери Нәфисәнең, метровкасын атлатып, эшләгән җирне үлчәп килүен сакалын аралаштыргалап карап торды.* Г. Бәширов.

МЕТРО'ЛОГ *и.* Метрология белгече.

МЕТРОЛО'ГИК *и.* Метрологиягә мөнәсәбәте булган.

МЕТРОЛО'ГИЯ *и.* Озынлык һәм авырлык үлчәүләре турындагы фән. *Метрология аппаратлары.* □ *1892 елда Д. И. Менделеев Үлчәүләрнең баш палатасына эшкә күчә. Биредә ул метрология буенча күп кенә фәнни эшләр башкара.* Химия.

МЕТРОНОМ *и.* Сугу тавышы белән кыска вакыт арасын билгели торган маятниклы прибор (төгәл үлчәү үткәргәндә, шулай ук музыка темпын билгеләгәндә кулланыла). *Кайдандыр буран эченнән, Совет башкаласының йөрәк тибеше кебек, метрономның бервәзлексез тыкылдаган тигез тавышы ишетелә.* Г. Әпсәләмов.

МЕТРОПОЛИТЕН *и.* Зур шәһәрләрдә гадәттә җир астыннан үткәрелгән, электрлаштырылган тимер юл. *Мәскәү метрополитены.* □ *Менә ул җир асты транспорты — метрополитен турында да, монорельслы, икенче төрле әйткәндә, асылмалы юллар турында да өстән-өстән сөйләп киткәндәй итте.* М. Хәсәнов.

МЕТРОПО'ЛИЯ *и. тар.* **1.** Борынгы Грециядә: башка илләр территориясендә төзелгән торак-авылларга (колонияләргә) мөнәсәбәттә шәһәр-дәүләт. *Борынгы Греция тарихы аерым шәһәр-дәүләтләр арасында, метрополияләр белән колонияләр арасында, Греция дәүләте белән Көнчыгыш дәүләтләре арасында барган сугышлар белән тулы.* Политэкономия.

2. Үзенең колонияләренә яки үзенә бәйле илләргә карата капиталистик дәүләт.

МЕТРОСТРОЙЧЫ *и.* Метрополитен төзүче.

МЕХ *и.* 1. Хайван тәнендә йомшак йон япмасы. *Төлке мехы. Куян мехы.* □ *Ул елларда безнең Казанда мехлар эшкәртү производствосы бик кызу үсә башлаган иде.* Ә. Еники.

2. Шундый япмасы булган җәнлекләрнең эшкәртелгән тиресе; бергә тегелгән берничә шундый тире. *Кеш мехыннан тегелгән бүрек.* □ [*Хатынның*] *пальто якасына --- песи йонына охшашлы мех тотылган.* Г. Бакиров.— *Без әле шундый мехлар эшләячәкбез: хәзергеләре алар алдында бик гади мехлар булып калырлар.* Р. Ишморат. || *с. мәгъ.* Шундый тиреләр эшкәртә торган. *Казан мех фабрикасы.* || *с. мәгъ.* Шундый тиредән тегелгән. *Мех яка. Мех бияләй.* □ *Өстендәге киеменә, аягындагы мех итегенә караганда, очучы булырга тиеш иде ул.* А. Шамов. *Ишан үзе бик шәп тышлы, кыска җыңле, мех әчле камзул сымак нәрсә --- кигән.* Ф. Әмирхан.

МЕХ- Кушма сүзләрдә „мех эшкәртүгә, җитештерүгә бәйләнешле" мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: *мехбаза, мехкомбинат.*

МЕХАНИЗА'ТОР *и.* Механизация белгече. *Сылу монда түгел хәзер. Ул кышка механизаторлар курсына укырга китте.* А. Тимергалин. || Машина, механизмнар белән эш итүче белгеч. *Еланлы елга чирәмлегенә башлаш участокта --- рәт араларын эшкәртүче механизаторлар күренде.* С. Рафиков.

МЕХАНИЗА'ЦИЯ *и.* Производствоны машиналар һәм механизмнар белән җиһазлау эше; кул хезмәте коралларын өлешчә яки тулысынча машиналар, механизмнар белән алмаштыру эше.— *Ни өчен колхозларны эреләндердек? Механизациягә, җир эшкәртү механизациясенә юл ачылсын, аның колачы киңәйсен өчен эреләндердек.* А. Расих. || *с. мәгъ.* Машина һәм механизмнар куллануга бәйләнешле. *Николай Николаевич икенче көнне үк совхозның механизация көчләрен барлыкка китерү эшенә тотынды.* И. Салахов.

МЕХАНИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф. к.* механикалаштыру. *Хәзер ул колхоз һәм совхоз терлек фермаларын механизацияләү һәм җылыту өчен пар көче белән эшли торган установкалар --- җитештерә.* Г. Әпсәләмов.— *Электрыгыз булмагач, ферманы механизацияләү планыгыз да үтәлмәгәндер инде.* Т. Гыйззәт.

МЕХАНИЗМ *и.* 1. Машинаның, аппаратның яки приборның аларны хәрәкәткә китерә торган эчке төзелеше. *Сәгать механизмы.* □ *Кунаклар --- буровойдагы механизмнарның, инструментларның торышын тәнкыйть күзлегеннән карап чыктылар.* Каз. утл. || Берәр төрле эш өчен махсус машина, җайланма. *Җир казу механизмнары.*

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса эчке төзелеше, эш системасы. *Дәүләт механизмы.* □ [*Әсәрдә*] *контрреволюция фронтын, бигрәк тә жандармерия, охранканың яшерен механизмын ачарга тиешле урынларны тагын бик нык көчәйтергә кирәк.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Физик, химик, физиологик һ. б. ш. күренешләрне барлыкка китерә торган хәл һәм процесслар җыелмасы. *Фикерләү механизмы. Кан әйләнеше механизмы.*

МЕХА'НИК I *и.* 1. Механика белгече. *Баш механик.* □ *— Шахтер буласың киләме? Рәхим ит! Укып инженер я механик буласың киләме? Анысына да ярдәм итәрбез.* Г. Бәширов.

2. Машиналарның дөрес эшләвен күзәтүче, аларны эксплуатацияләү белән җитәкчелек итүче инженер, техник яки эшче.— *Газиз бүген механик икән, иртәгә аның танкист булуы да мөмкин.* А. Әхмәт.

МЕХА'НИК II *с.* 1. Механизмнар башкара торган процессларга, күренешләргә мөнәсәбәте булган. *Механик эш. Механик энергия.*

2. *к.* механистик. *Механик материализм.* || *күч.* Эшнең асылына тиешле игътибар бирми, күренешләрнең катлаулы һәм үзенчәлекле булуын исәпкә алмый торган; берьяклы. *Мәсьәләгә механик караш.* □ *— Бу чагыштыруыгыз урынлы түгел. Механик чагыштыру гына бу.* Ш. Камал.

3. Механизмнар ярдәмендә эшли торган. *Механик пычкы.* □ [*Тамара, проектны карап:*] *Сез аны ничек дип — улак япкычы дип атыйсызмы? — Әйе, механик япкыч.* Н. Исәнбәт.

4. *күч.* Аң эшчәнлегенә бәйләнмәгән, аңсыз, автоматик башкарылган. *Баязит зиндан әлифбасын өйрәнде. --- Бара торгач, бармаклар үзеннән-үзе механик рәвештә кирәкле санны чиертә торган булдылар.* Г. Ибраһимов. *Назыйрә механик ияру түгел. Киресенчә, ул шагыйрьләр арасында бер үк вакытта тәҗрибә уртаклашу да һәм иҗат ярышы да.* Х. Госман.

МЕХА'НИКА *и.* 1. Физиканың пространствода җисемнәр хәрәкәте законнарын өйрәнә торган бүлеге.— *Батарея командиры булу өчен математика, баллистика һәм механиканы белергә кирәк.* А. Шамов. || Техниканың хәрәкәт һәм көчләр турындагы тәгълиматын практик бурычларга яраклаштыру мәсьәләләрен өйрәнә торган бүлеге. || *с. мәгъ.* Машиналар, төрле механизмнар эшләп чыгаруга, ремонтлауга мөнәсәбәте булган. *Механика цехы. Механик яруг түгел. Механика заводы.* □ *Варис белән Вәсилә --- механика мастерское янына күтәрелә башладылар.* М. Хәсәнов.

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса сере, катлаулы төзелеше, асылы.— *Син мәсьәләне механик рәвештә чишәсең.— Акча механикасы шулай булгач, нихәл итәрсең!* Ш. Камал.

МЕХА'НИКАЛАШТЫРУ *ф.* Машиналар, механизмнар белән җиһазлау; кул хезмәтен машиналар һәм механизмнар эше белән алмаштыру.— *Авыл хуҗалыгын яңа нигезгә коруда, механикалаштыруда, электрлаштыруда, ашлык хәзерләү эшләрендә --- зур уңышларга ирешелде.* К. Тинчурин.— *Докладчы --- урман эшен механикалаштыру, аңа даими кадрлар булдыру, урман кисүчеләр алдында торган зур бурычлар турында сөйләде.* Г. Әпсәләмов.

МЕХА'НИКЛЫК *и.* Механик (1 мәгъ.) хезмәте, һөнәре.

МЕХАНИСТ *и. филос.* Механицизм тарафдары.

МЕХАНИ'СТИК *с.* Механицизм принципларына нигезләнгән. *Механистик теория. Механистик материализм.* □ *Механистик материалистлар аң, фикер һәр материягә хас сыйфат дип белдерәләр.* М. Абдрахманов.

МЕХАНИСТЛА'РЧА *рәв.* Механистларга хас булганча, механистлар шикелле. *Иске материализмның „тормыш аңны билгели" дигән карашын алып та, шул ук вакытта диалектик материализмның аң үзе дә тормышка тәэсир ясый, --- дигән карашын онытсак, мәсьәләгә берьяклы, механистларча караган булыр идек.* Г. Нигъмәти.

МЕХАНИЦИЗМ *и.* Табигатьтәге сыйфат күптөрлелеген бердәй материя кисәкчекләренең механик хәрәкәте дип кенә карап, үсешнең катлаулы закончалыкларын гади механик законнар белән генә аңлатырга тырыша торган, диалектикага капма-каршы философик юнәлеш.

МЕХАНОТЕРАПИ'Я *и.* Авыруларны махсус аппаратларда физик күнегүләр белән дәвалау методы.

МЕХЛЫ *с.* Мехтан (2 мәгъ.) тегелгән, мех тотылган, эченә мех куелган. *Өстәл янына утырган кеше аркасына мехлы пальто салган.* Ш. Камал.

МЕХЧЫ *и.* **1.** Мех белән сәүдә итүче.

2. Мех фабрикасы эшчесе; мех эшкәртү буенча белгеч. *Мехчылар клубы.* □ *Әйбәт безнең мехчылар, Бар да уңган эшчеләр.* Р. Ишморат.

МЕЦЕНАТ *и. кит.* Буржуаз-дворян җәмгыятьтә: фән һәм сәнгать белән кызыксынып, аның файдасына материаль һәм мораль ярдәм күрсәтүче бай кеше. *Бу шәһәр университет шәһәре буларак та, сәнгать сөюче меценатлар торган җир буларак та атаклы.* Каз. утл.

МЕЦЕНАТЛЫК *и. кит.* Меценат эшчәнлеге.

Меценатлык итү — меценат эшчәнлеге күрсәтү.

МЕ'ЦЦО-СОПРА'НО *и. муз.* Югарылыгы буенча сопрано белән контральто арасында торган хатын-кыз тавышы. || Шундый тавышлы җырчы.

МЕЩАН *и.* **1.** Революциягә кадәр Россиядә шәһәр вак сәүдәгәрләреннән, һөнәрчеләрдән, вак хезмәткәрләрдән һ. б. ш. торган катлау вәкиле. *Без Г. Камал әсәрләрендә кеше хакын ашап, симереп котырынган, йөгәнсезләнгән байларны, сәүдәгәрләрне, черек буржуа җәмгыяте тудырган шәһәр мещаннарын күрәбез.* М. Гали. *Бәйрәм диеп, мещан кызларыдай, Ашыгып-ашыгып күлмәк текмибез.* Һ. Такташ.

2. Тар карашлы, шәхси интересларын гына күзәтүче кеше. *Гаяз тагын дәвам итте: — Син надан гына түгел, син консерватор, син мещан.* М. Әмир. *— Мин сине олы йөрәкле, кыю егет дип йөрсәм, син, әнвәр, вак җанлы мещан икәнсең.* Р. Ишморат.

МЕЩА'НКА *и.* Мещан хатын-кыз. *Сиражиның хатыны Гөлҗиһан — чеп-чи мещанка.* М. Гали. *— Мин саксон фарфорлары белән ас мехыннан тегелгән манто кебек әйберләргә алданучы арзанлы мещанка түгел.* Ш. Хөсәенов.

МЕЩАНКАЛЫК *и. к.* мещанлык.

МЕЩАНЛАШУ *ф. к.* мещанлану. — *Җомагыл, син көннән-көн мещанлашып барасың.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

МЕЩАНЛАНУ *ф.* Мещанлык сыйфатлары күрсәтү, мещанга әйләнү.

МЕЩАНЛЫК *и.* Мещаннарга хас психология, идеология, үз-үзеңне тотыш. *Хәлил, мәхәббәт хисләренә бирелеп, бай кызына өйләнә һәм мещанлык колы булу куркынычы алдында кала.* Г. Халит. *Булат тагы чәнчеп өстәр: ләкин ник булыгыз, интеллигенциянең бер катлавы, кызарып, социализм дип йөри дә, ахырдан барып, мещанлык сазына бата, шуңардан сакланыгыз, дияр.* Г. Ибраһимов.

МЕЩАННА'РЧА *рәв.* Мещаннарга хас булганча, мещаннар кебек. *Бәлки Хәлим чынлап та мещаннарча фикер йөртәдер.* И. Гази.

МЕҖЕР-МЕҖЕР *аваз. иярт.* Әкрен генә, күбекләнеп сыеклык кайнау тавышын белдерә.

Меҗер-меҗер итү (килү) — меҗер-меҗер тавышлары чыгару. — *Балык ул тыныч утта ярты сәгать кайнасын. Меҗер-меҗер итеп, талгын гына.* Г. Мөхәммәтшин.

МЕҖ-МЕҖ *аваз. иярт.* Аңлашылмый торган авазларны эченә алган әкрен тавышны, әкрен генә авыз эченнән сөйләнүне белдерә.

Меҗ-меҗ итү (килү) — меҗ-меҗ тавышлары чыгару, авыз эченнән әкрен генә сөйләнү.

◇ **Меҗ-меҗ (килеп) утыру** — нәзберекләнеп, сайланып, ашар-ашамас утыру.

МЕҖЕЛДӘШУ *ф.* Үзара меҗелдәү. *Татар агайәне --- сызып кына ачылган иреннәре ирек биргән чаклы меҗ-меҗ меҗелдәшә дә кет-кет кеткелдәп көлә.* И. Рәмиев.

МЕҖЕЛДӘҮ *ф.* Меҗ-меҗ итү. [*Бибиҗамал апа*], *яулык почмагы белән авыз-борынын каплап, йөзен читкә борды һәм меҗелдәп елап җибәрде.* Ш. Хөсәенов.

МЕҢ *сан.* **1.** 1000 нең сан һәм микъдар атамасы. *Меҗ килограмм. Меҗ километр.* □ *Бай, кырык меҗ сумлык алтын аласы урында, үзе өч меҗ сум акчасыннан колак кага.* М. Гали.

2. *сөйл.* Бик күп, чиксез күп. *Меңне сөйләгәннән берне эшләп күрсәтү артыграк.* Мәкаль. — *Халык меҗ күзле бит ул, берсе күрмәсә, берсе күрер.* М. Әмир. || *каб. форм.* **меҗ-меҗ.** Бик күп, меңләгән. *Ай баралар, ел баралар [егетләр], меҗ-меҗ чакрым җир үтәләр.* И. Туктар. *Күрсәң иде Идел буйларын, Ил өстендә төтен буйлавын; Аз-аз гына бер җил исүдән Җирдә меҗ-меҗ чәчәк уйнавын.* Н. Исәнбәт.

3. *и. мәгъ. күпл.* **меҗнәр.** Әллә ничә меҗ кеше; меҗнәрчә кеше. *Сүзләрен ул меҗнәр йөрәгеннән Җыеп алып сөйли шикелле.* Х. Туфан. *Ничек үлим, берләр меҗнәр өчен, Меҗнәр берләр өчен торганда.* Һ. Такташ. || Бик зур байлык, күп акча турында. *Ул меҗнәр белән генә эш йөртә.*

4. *күч.* Бик күп тапкыр, бик күп мәртәбә. *Дошманыңнан бер саклан, яман дустан меҗ саклан.* Мәкаль.

Меҗ башы — борынгы заманда хәрби ополчение башлыгы.

◇ **Меҗ бәла белән** — гаять зур кыенлыклар белән. *Бикмуш бабай --- тимерне коры имән утынныннан төшкән кызу күмергә салып кыздырды. Меҗ бәла белән бөкте аны.* Г. Гобәй. **Меҗ дә беренче тапкыр (кат)** — бик күп мәртәбә кабатлап. *Җәләл кәнәфигә кырын ята да меҗ дә беренче катка янәдән сорый башлый.* Г. Ибраһимов. **Меҗ дә берне белү** — бик күпне, кирәк-кирәкмәсне дә белүче кеше турында. *Бик инде күпне, меҗ дә берне белә торган нәрсә [бу Маннур].* М. Хәсәнов. **Меҗ (меҗнәр) яшә!** — озак еллар яшә. *Яшә, тугры караш, төпле гакыл, меҗнәр яшә, хезмәт!* Г. Тукай. **Меҗ рәхмәт** — бик күп рәхмәт (чиктән тыш канәгатьлек хисен белдергәндә әйтелә). *Синең белән мин хыялларда гына була алырлык тиңсез рәхәт, сөенеч һәм бәхет дөньясында яшәдем. Бергә яшәгән шушы өч ай гомер өчен меҗ-меҗ рәхмәт сиңа.* Г. Бәширов. **Меҗ яшәрле(к)** — бик озак еллар яшәгән, мең елга кадәр яшәгән. *Борын-борын заманда яшәгәннәр бу тауда йөз башлы аждаһалар, Меҗ яшәрле юхалар.* М. Җәлил. *Үзе үлсә дә, „меҗ яшәрлек имән булып", Яшьлегенә „һәйкәл булып" эше калды, эзе калды.* Каз. утл.

МЕҢГЕР-МЕҢГЕР *аваз. иярт.* Әкрен генә үз алдына сөйләнгәндә, укыганда чыккан тавышны белдерә. *Ул чынлап та башкалар кебек меңгер-меңгер дәрес ятлап баш ватмый.* Г. Ибраһимов.

МЕҢГЕРҮ *ф. сөйл. к.* менгерү. *Илдар Маратны җитәкләп күперчеккә меңгерде.* Г. Гобәй. *Ул ишектән керүгә, Рәхмәтулла карт ачуланып бер күтәрелеп карады да, күзлеген маңгаена меңгереп, сәке өстеннән сикереп төште.* М. Гали.

МЕҢЕНЧЕ *Тәрт. саны. к.* мең. *Меңенче кат сорау белән карыйм әтигә.* Ш. Маннур. *Хәзер Ишнияз --- бары тик миллиметрның меңенче өлеше — микроннар белән генә эш итә.* Г. Әпсәләмов.

МЕҢЛЕ *с. к.* меңлек. *Петроградта хәрби революцион --- комитет илле меңле гарнизонга үзенең боерыкларын йөртә.* Ш. Камал.

МЕҢЛЕК *с.* Төп саннардан соң килеп: шул санча мең берәмлекне эченә алган. *Ике меңлек тиражның бер өлеше казах арасында йөри торган таныш сәүдәгәрләргә тапшырылды. Күп тә үтмәде, китаплар сатылып беттеләр.* Ә. Фәйзи. *Врангель --- 40 меңлек гаскәр белән Донбасс уңаена һәм Мәскәү юлына*

таба көчле һөҗүм башлаганнан соң, бу дивизиягә каты сугышларда катнашырга туры килде. Г. Бәширов. || Шул кадәр мең күләмендәге; шул кадәр мең бәя торырлык. *Ун меңлек товар.*

МЕҢЛӘГӘН *Чама саны.* Берничә мең; бик күп сандагы. *Казанда мәдәният мәйданы киң, аның университеты, аның меңләгән студенты, профессоры, гыйлем-фән әһелләре бар.* З. Бәширн.— *Без, меңләгән, йөз меңләгән совет яшьләре, яхшы атларга, корыч танкларга, җитез самолетларга утырырбыз да совет кешеләренең нахакка аккан каннарын даулар-быз.* Т. Гыйззәт.

МЕҢЛӘП *Чама саны. к.* мең. *Меңләп кешенең шатлыклы йөрәк талпынуы белән атылып чыккан көчле „ура" тавышы бөтен чиркәү эчен яңгыратты.* Ш. Усманов. || *каб. форм.* **меңләп-меңләп.** *к.* меңәрләп. [*Чехларга*] *байлар бирде ярдәмнәрне меңләп-меңләп, Кызыл маллар, ситсыларны иңләп-иңләп.* Г. Камал. *Котырган эт — канлы фрицларны Без алар белән бергә Йөзләп кенә түгел, меңләп-меңләп Йөзтүбән салдык җиргә.* Ф. Кәрим.

МЕҢЛӘТӘ *рәв.* Мең тапкыр, бик күп мәртәбәләр.— *Ышанығыз, әнием, бу хәл минем сезгә булган мәхәббәтемне меңләтә көчәйтә.* Г. Гобәй.

МЕҢНӘ'РЧӘ *Чама саны.* Әллә ничә мең; бик күп мең. *Меңнәрчә, миллионнарча кар энҗеләре җемьҗем итеп балкыйлар.* Г. Әпсәләмов. *Кешеләр сугыша, кан коя; Киселә меңнәрчә гомерләр.* М. Җәлил.

МЕҢЧЕ *и.* 1. Сменага ун, аннан артык эш нормасы үти торган алдынгы эшче. *Меңчеләр хәрәкәте.*

2. Самолетта, машинада мең километр юл үткән очучы, шофер; парашют белән мең тапкыр сикергән кеше.

3. *тар.* Монгол-татар яулап алучылары гаскәрендә мең сугышчыдан торган отрядның башлыгы; мең башы.

МЕҢЬЯФРАК *и. бот.* Оешма чәчәкләләр семьялыгыннан каурый сыман, киртләч-киртләч вак яфраклы, бик исле үлән үсемлек; ак мәтрүшкә; *русчасы:* тысячелистник.

МЕҢӘР 1. *Бүл. саны. к.* мең. *Акчаның кадерен белмәдем, меңәр сумлык туннар кидем.* Ш. Мөхәммәдев.— *Алпавытка каян килгән соң меңәр десятина җир? Безнең нәсел-нәсәпне талап җыйган байлык бит ул.* К. Нәҗми.

2. *к.* меңнәрчә. *Нинди генә җирләр үтмәдем мин, Каным белән җирне сугарып, Меңәр чакрым буе җәяү йөрдем, Штык очы белән юл ярып.* Ә. Ерикәй. *Керсә монда берәү, меңәр еллык Борынгылык белән уралыр.* Ш. Мөдәррис.

МЕҢӘРЛӘГӘН *Чама саны. к.* меңләгән. *Хәзер генә шул бәдбәхет Таһирны Баш иттем мин меңәрләгән гаскәргә!* Ф. Бурнаш. *Шахта беркемнән дә сорап тормаган, меңәрләгән терәүләргә карамый, --- убылган да төшкән.* М. Гафури.

МЕҢӘРЛӘП 1. *Чама саны. к.* меңләп. [*Йолдызларның*] *диңгезгә төшкән шәүләләре --- диңгезнең төбенә куәтле һәм гаять матур электрик лампаларын меңәрләп яндырып куйган шикелле итеп күзләрне алдый иде.* Ф. Әмирхан. *Төн йокысын бүлеп вак кисәккә, Мендәрләрен меңгә бөгәрләп, Уйлыйлардыр һаман шул турыда Башкалар да йөзләп, меңәрләп.* Ш. Маннур.

2. *Бүл. саны. к.* мең. *Эшчеләр санын, номерлар тагып, Меңәрләп кенә саныйлар анда.* К. Тинчурин.

МЕҢӘҮ *Җыю саны. к.* мең. *Чурай кыз бездә берәү түгел, Алар меңәү.* М. Җәлил.

МИ I *и.* 1. Кеше һәм хайваннарда нерв системасының үзәк өлеше — баш сөягенә һәм умыртка сөяге каналына урнашкан матдә. *Арка мие. Ми селкену.* □ *Аның мие сызлый, коточкыч авырттырып, колаклары шаулый.* Г. Бәширов. *Көньякның кояшы тәннәрне Көйдереп, миләрне кайната.* Ә. Исхак. || Фикерләү органы буларак, кешенең баш мие. *Илсөярнең миендә капма-каршы бу ике хиснең әле берсе өстенлек итте, әле икенчесе өстенлек алды.* Г. Гобәй. *Куркыныч бер уй Газинурның миеннән яшен тизлеге белән үтеп китте.* Г. Әпсәләмов.— *Миендә агулы сөрем сынең, аерым хуҗалык сөреме. Өянгең дә, теш сызлавың да әнә шуннан килә. Аңладыңмы?* Р. Ишморат.

2. *сөйл.* Акыл, акыл сәләте; аң. *Буй озынлыгыннан ни файда, Башыңда миең аз булса.* Мәкаль. *Кимегә акыл кирәкми, мулайтырга ми кирәк.* Әйтем. *Мулла-мунтагай дин исеменнән --- халыкның миен агулый.* Г. Ибраһимов.

◇ **Ми кабару (кызу, күперү)** — аңгы-миңге хәлгә килү; нервлар бик нык киеренкеләнү. *Көтелмәгән бу күренештән егетнең мие кызды, башы шаулады.* К. Тинчурин. *Бу бер елда баштан кичкәннәрдән Ми күперде, йөрәк кабарды.* М. Җәлил. **Ми кату** — *к.* баш кату.— *Тукта әле, мин аны нигә кыстый-кыстый Ләлә янына җибәрәм соң... Эшне отыры боза гына бит инде ул. Ми дә катып бетте инде болар белән.* М. Фәйзи. **Ми кибү** — аңгыралану, акылга зәгыйфьлек килү; аптырап-алҗып бетү.— *Мие кипкән, күрәсең [Халикәның]. Башы эшләми, нәгъләтнең!* Ш. Камал. **Ми күгәрү** — акыл эшчәнлеге зәгыйфьләнү. *Сезнең миләрегез күгәргән, Сезгә сугыш сөреме сырышкан.* Ә. Ерикәй. **Ми кузгалу (төшү)** — бик каты егылганда яки башны бик каты бәргәндә минең селкенүе сәбәпле бик каты баш авырту. **Ми түнү** — аңгыралану, миңгерәүләнү, аңлау сәләтен югалту.— *Мин яшь чагымда --- минем башым юеш мамык тутырган бер тубалга әйләнде. Мием түнде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Ми әйләнү** — *к.* баш әйләнү (2, 3 мәгъ.).— *Уф-фү!.. Мием әйләнде... Харап булдык!.. Харап булдык!..* Г. Ибраһимов. **Ми утырту** — халык медицинасында ми кузгалу авыруын дәвалау ысулы: башны сөлге белән ми күчкән дип исәпләгән урынга капма-каршы якка туры китереп уратып тоталар һәм тоткан урынга икенче кул белән каты гына итеп берничә мәртәбә сугалар; шуннан, янәсе, ми кире үз урынына күчә, баш авырту туктый. **Ми черетү** — 1) бушка, файдасызга акыл эшчәнлеге сарыф итү. *Шәкерт --- үзенең яшьлек рәхәте күрмәве белән башлый, җиде яшьтән алып, тар, кысык, сасы татар мәдрәсәләрендә изелеп, ми черетүен сөйли.* Г. Ибраһимов; 2) файдасыз, мәгънәсез сөйләшүләр, бәхәсләр белән җәфалану, йөдәү турында. [*Сафаров:*] *Их, бәхетле халык Кырымга китә. --- Д без монда Кузнецовлар һәм Дубцовалар белән җәнҗәллашып ми черетергә калабыз.* Ш. Камал. **Мигә йөгерү** — акыл, ми эшчәнлегенә тәэсир итү (исерткеч эчемлек турында). *Кымызның кәефе мигә йөгерде.* Г. Ибраһимов. **Мигә сеңү** — бик яхшы аңлашылу, хәтердә нык сакланы. **Мие черегән** — аңгыра, акылга тулы түгел. *Студент миңа гаҗәпсенеп карап тора: бу кадәр мие черегән кеше булыр икән!* Ф. Әмирхан.

МИ II *и. муз.* Музыкаль гамманың өченче авазы; шул авазны белдерә торган нота.

МИВӘ *и. иск.* Җимеш, җиләк-җимеш. *Бик тәмле ризыклардыр инде ул мивәләр.* Г. Бәширов.

МИГЕРДӘҮ *ф.* Әкрен генә кычкырган кәҗә тавышы турында; шуна охшаган тавыш чыгару (мәсәлән, көлгәндә). [*Хәйретдин:*] *Кытыкны китерәсең лә. Хи-хи-хи...* [*Галимә:*] *Әбәү! Кәҗә тәкәсе төсле мигерди!* Ш. Камал.

МИГРА'ЦИЯ *и.* 1. *кит.* Халыкның бер өлкәдән икенче өлкәгә яки бер илдән икенче илгә күчүе.

2. *биол.* Тереклек шартлары үзгәрү яки билгеле бер үсеш циклы үтү сәбәпле, терек организмнарның бер урыннан икенче урынга күчүләре. *Кошлар миграциясе.* □ *Балыкларның --- миграцияләре уылдык чәчү белән генә түгел, туклану белән дә бәйләнгән.* Зоология.

3. Нинди дә булса элементларның, күзәнәкләрнең бер урыннан икенче урынга күчүләре.

МИГРА'ЦИЯЛӘНҮ *ф. кит.* Күчү, күчеп йөрү; миграция ясау. *Нефть — сыеклык һәм ул бер урыннан башка урынга китәргә, комташларның микроскопик күзәнәк каналлары --- аша күчәргә, миграцияләнергә мөмкин.* Нефть тур. хикәяләр.

МИГРЕНЬ *и.* Баш өянәге (башның бер як ярты-сында вакыт-вакыт көчле авырту барлыкка килүдән гыйбарәт нерв авыруы).— *Бүген анакайның мигрене кузгалды.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Мигреньне дәвалау өчен билгеләнгән. *Мигрень карандашы.*

МИЕЛИТ *и. мед.* Арка миенең ялкынсыныу.

МИЖАН *с. диал.* Сынмый торган, йомшак, сыгылмалы. *Мижан юкә.* □ *Кулымдагы мижан көлтә бавын Бора-бора уйда югалам.* Ш. Маннур.

МИЗАН *и. иск. кит.* Үлчәү, бизмән. *Минем сөюләрем артык килер, Мизаннарга салып үлчәсәк.* Җыр. | *күч. Насыйри халык авызындагы әкиятләрне, риваятьләрне җыя; боларның бер өлеше, башка материаллар белән чагыштыру мизанныннан үткәч, тарих өчен эшкә яраклар.* Г. Ибраһимов.

МИЗАНСЦЕ'НА *и. театр.* Спектакльдә, уен барышына карап, артистларның, сәхнә җиһазларының урнашу тәртибе. *Спектакльдә бернинди декоратив эффектлар да, мизансцена трюклары да юк. Артистлар шулкадәр гади һәм ышандырырлык итеп уйныйлар ки, әйтерсең лә чын тормыш үзе сәхнәгә менгән.* Сов. әд.

МИЗАНТРОП *и. кит.* Кешеләрне яратмаучы, кешеләргә нәфрәт белән караучы, алардан читләшүче кеше.

МИЗАНТРО'ПИК *с. кит.* Мизантропка хас. *Мизантропик характер.*

МИЗАНТРО'ПИЯ *и. кит.* Кешеләрне күрә алмаучылык, кешеләргә нәфрәт белән карау мөнәсәбәте, алардан читләшү хәле.

МИЗГЕЛ *и.* 1. Нинди дә булса эш-хәл башкарыла, булып үтә торган вакыт. *Мизгеле җитми таң атмас.* Мәкаль. *Печән өсте! Беренче мәхәббәтем төслерәк гажәеп мизгел!* Ә. Баянов. *Һәр җимешнең үз мизгеле бар.* Мәкаль. || *иск.* Елның билгеле бер вакыты; фасыл. *Җәй мизгеле. Кыш мизгеле.*

2. Бик кыска вакыт арасы. *Күңелле шау-шу бер мизгелгә тынып калды.* М. Әмир. *Җыр бетте. Матрос башта бер генә мизгелгә аптырап калды.* С. Сабиров.

3. Очрак, хәл. *Авыр мизгелне хәл итүемне үзем тоеп торам.* Н. Исәнбәт. *Атканда, чапканда, хөрлеккә йөз төбәп, булды мизгеллэр — капландык йөз-түбән.* Р. Фәйзуллин.

МИЗГЕЛСЕЗ *рәв.* 1. Вакытлы-вакытсыз, теләсә кайчан. *Торлаксыз үскән колан мизгелсез юшап, мизгелсез утлар.* Мәкаль.

2. *с. диал.* Тотнаксыз, әдәпсез; чаманы белми торган. *Мизгелсез кеше.*

МИЗГЕЛСЕЗЛӘНҮ *ф. диал.* Мизгелсезгә (2 мәгъ.) әйләнү; тыйнаксызлык, әдәпсезлек күрсәтү.— *Азма, әнекәш! Биредә алай мизгелсезләнергә ярамый.* Н. Исәнбәт.

МИКА'ДО *и.* Япония императоры титулы; шул титулга ия булган кеше. *Бичара Рәшит казый гына, микадо мөселман була дигән булып, һәммә татар галәмен алдый язган иде.* Г. Тукай.

МИКОРИ'ЗА *и. бот.* Гөмбә җепселләренең (гөмбәчекләрнең) югары төзелешле үсемлекләрнең тамыры белән кушылуы, кушылып үсү күренеше. *Күпчелек агачларның нормаль үсеше микоризадан башка мөмкин түгел: гөмбә җепселләре агач тамырларының эченә үтеп керәләр һәм аны дым, туклыклы матдәләр белән тәэмин итәләр.* Биология.

МИКРО- Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) бик кечкенә, вак, мәсәлән: **микроорганизм, микродулкыннар, микротопонимика, микрометеорит;** 2) бик кечкенә предметларны, зурлыкларны тикшерү яки үлчәү белән бәйләнгән, мәсәлән: **микроанализ, микробиология;** 3) сүзнең икенче кисәгендә белдерелгән төп үлчәү берәмлегенең миллионнан бер өлеше, мәсәлән: **микровольт, микрофарада, микроампер, микромиллиметр.**

МИКРОАШЛАМА *и.* Составында үсемлекләргә бик аз микъдарда гына кирәкле элементлары (бор, бакыр, марганец, цинк һ. б.) булган ашлама. *Микроашламалар уңышны арттыралар һәм үсемлекләрнең төрле авыруларга каршы торучанлыгын көчәйтәләр.* Химия.

МИКРОБ *и.* Микроскоп аркылы гына күренә торган бер күзәнәкле тереклек иясе; бактерия. *Йогышлы микроблар.* □ *Катык оеткanda, микроблардан нинди ярдәм көтсәк, силос хәзерләгәндә дә шундый ук ярдәмне алабыз.* А. Расих. *Үлем микроблары хәзер күкрәгемдә, Алдап булмас ахры аларны.* һ. Такташ.

МИКРОБИО'ЛОГ *и.* Микробиология белгече.

МИКРОБИОЛО'ГИК *с.* Микробиологиягә мөнәсәбәте булган. *Микробиологик тикшеренүләр. Микробиологик юл белән аксым алу.*

МИКРОБИОЛО'ГИЯ *и.* Биологиянең микроорганизмнарны өйрәнә торган бүлеге.

МИКРОБЛЫ *с.* Микробка мөнәсәбәте булган. *Микроблы күзәнәкләр.* || Микроблар тудыра торган. *Микроблы инфекция.*

МИКРОДӨНЬЯ *и. к.* микрокосм.

МИКРОКЛИ'МАТ *и.* 1. Зур булмаган пространстволарга караган, шул урынның (урман, кыр, сазлык һ. б.) үзенчәлекләре белән бәйле климат.

2. *күч.* Берәр коллектив эчендәге үзара мөнәсәбәтләр, эшкә мөнәсәбәтле хәл-шартлар турында. *Хәзер социаль психология бик модада. „Үз канатың астындагы микроклиматны тирәнтен белү бик тә әһәмиятле", диләр.* Э. Касыймов.

МИКРОКЛИ'МАТЛЫ *с.* Микроклимат булдырылган. *Микроклиматлы бүлмә* (мәсәлән, космик корабльдә).

МИКРОКЛИМА'ТИК *с.* Микроклиматка мөнәсәбәте булган. *Микроклиматик тикшеренүләр.*

МИКРОКОСМ *и. кит.* Кечкенә зурлыклар (атомнар, электроннар һ. б. ш.) дөньясы.

МИКРОМЕР *и. махс.* Машина детальләренең озынлык-калынлыкларын үлчи торган прибор. *Пружиналы микромер.*

МИКРОМЕТР *и. махс.* Бик кечкенә озынлыкларны төгәл үлчәү коралы. *Кулына микрометр тотып, цех буйлап --- Парамон Васильевич килә иде.* Г. Әпсәләмов.

МИКРОМЕ'ТРИК *с.* Микрометриягә мөнәсәбәте булган. *Микрометрик үлчәүләр.*

МИКРОМЕ'ТРИЯ *и.* Физиканың озынлыкларны төгәл үлчәү белән шөгыльләнә торган бүлеге.

МИКРОН *и.* Метрның миллионнан бер өлешенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге. || *с. мәгъ.* Микрон зурлыгындагы.— *Без микрон төгәллек белән эшлибез,*

безгә күзләрнең тазалыгын саклау бик кирәк. Г. Әпсәләмов.

МИКРОНЛАП *рәв.* Микрон үлчәме, исәбе белән. *Миллион чакрымлап мин үтәр юл Микронлап алдан салынган.* С. Баттал.

МИКРООРГАНИЗМ *и.* Үсемлек һәм хайваннар дөньясында гади күз белән күреп булмый торган бик вак тереклек ияләре (микроблар, микроскопик суүсемнәр һ. б.). *Авыру тарата торган микроорганизмнар.*

МИКРОПОР *и.* Бик вак, микроскопик күзәнәкле йомшак резин. || *с. мәгъ.* Шундый резиннан эшләнгән. *Әгәр дә ул аның киемнәрен игътибар итеп караган булса, кызның --- гади ефәк оек өстеннән кигән микропор табанлы, уртача гына үкчәле көрән туфлидән икәнен күрер иде.* М. Әмир.

МИКРОРАЙОН *и.* Районның нинди дә булса максатлар өчен бүленгән иң кечкенә берәмлеге. *Шәһәр читендәге буш урында тугыз мең кешелек яңа микрорайон төзиячәкләр иде.* М. Маликова. *Роно мине үзебезнең микрорайондагы тәрбиячеләргә методик җитәкче итеп билгеләде.* Э. Касыймов.

МИКРОСКОП *и.* Гади күзгә күренмәслек әйберләрне яки аларның кисәкләрен бик нык зурайтып күрсәтә торган линзалар системасыннан гыйбарәт прибор. *— Менә, гади күз белән караганда бу таш валчыгының төсен белүе дә кыен, ә микроскоп аша карагач, аның төсе дә, кыяфәте дә, сыйфаты да ачык күренә.* А. Әхмәт.

МИКРОСКО'ПИК *с.* 1. Микроскоп ярдәмендә башкарыла торган. *Микроскопик анализ. Микроскопик тикшеренү.*

2. Бик кечкенә, микроскоп аша гына күренә торган. *Микроскопик суүсемнәр.*

МИКРОСКО'ПИЯ *и.* Микроскоп төзелеше, аны куллану һәм микроскопик препаратлар хәзерләү турындагы практик фән; микроскоп ярдәмендә нәрсә дә булса тикшерү эше.

МИКРОСТРУКТУ'РА *и. махс.* Каты әйберләрнең микроскоп аша күренә торган төзелеше. *Металл микроструктурасы.*

МИКРОФЛО'РА *и.* Табигый мохитта (туфракта, һавада, ашамлык әйберләрендә һ. б.) үсемлек микроорганизмнары җыелмасы.

МИКРОФОН *и.* Аваз тирбәнешләрен электрик тирбәнешләргә әверелдерү приборы (тавышны көчәйтү яки ераккa тапшыру өчен кулланыла). [*Хәятның*] *күзләре сәхнә алдына куелган микрофонга төште.* Г. Кутуй. *Миндаров, --- микрофонын авызына якын ук китереп, залны тагын бер мәртәбә тыныч ланырга чакырды.* Г. Ахунов.

МИКРОФОТОГРА'ФИЯ *и.* 1. Бик вак әйберләрне микроскоп ярдәмендә рәсемгә төшерү.

2. Микроскоп ярдәмендә төшереп алынган объектның зурайтылган сурәте.

МИКРОЭЛЕМЕНТ *и.* Үсемлекләрдә һәм терек организмнарда бик аз микъдарда гына була торган химик элемент (процентның йөзенче, меңенче һәм аннан да кечкенәрәк өлешләрендә). *Микроэлемент препаратлары. Микроэлементлар белән туендырылган махсус ашлама.*

МИКСТУ'РА *и. мед.* Берничә матдә кушылмасыннан торган сыек дару. *Ул, врачлар биргән микстуралар көчәнә генә ышанмыйча, тайгадан ниндидер дару үләннәре җыеп алып кайта.* Ә. Маликов.

МИКЪДАР *и.* 1. Күләм, чама; үлчәм. *Берничә микъдар мәһәр салып, кызны килешкәч, колак сөенчесе бирәләр.* К. Насыйри. *Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга, Кирәкми тик ашарга дип яшәргә.* Г. Тукай.

2. Чаклы, кадәр; чамасы. *Ярты сәгать микъдар вакыт үтте.* З. Бигиев. *Кандала очынып менеп китте шулай, Бер секунд микъдар заман үтте бугай.* Ш. Бабич.

3. *филос.* Сан. *Микъдарның сыйфатка әйләнүе. Күренешләрне сыйфат һәм микъдар ягыннан өйрәнү.*

4. *иск.* Күләм, масштаб. *Бу эш әле, гомум Россия микъдарында алганда да, тиз вакытта гына кирәгенчә куелып җитә алмаячактыр.* Ф. Әмирхан.

Микъдар саны *лингв.* — саннарның предметлар санын, микъдарын яки гомумән абстракт санны белдерә торган төркемчәсе. *Микъдар саннары арасында семантикасының киңлеге белән бер саны аерылып тора.* Д. Тумашева.

МИКЪДАРИ *с. иск. кит. к.* микъдарлы. *Микъдари үзгәреш.*

МИКЪДАРЛЫ *с.* Микъдарга (3 *мәгъ.*) мөнәсәбәтле; санлы. *Микъдарлы бәйләнеш. Микъдарлы чагыштырма.*

МИКЫЛДАП: микылдап тору — *к.* мимылдау 1. *Камиләнең --- кабарган күкрәкләренә, өрелеп торган таза беләкләренә карыйлар да: — Камилә гә кияүгә бару килеште, микылдап тора! — диләр әүвәлге таныш-белешләре.* М. Әмир.

МИКӘН *кис.* Сорауны белдерә. *Тальян гармоньның телләре көмеш микән, җиз микән; Сөешеп йөргән ярлар белән кавышыр көннәр тиз микән.* Җыр. *Күз карашың никтер уйчанланды, Син беләсең микән, юк микән.* С. Хәким.

МИКӘННИ *кис. сөйл. к.* микән. *Киек казлар кыйгылдаша, Җырлашалар микәнни?* Х. Туфан.— *Шулай ук моннан китәргә туры килер микәнни!* Г. Камал.

МИЛАДИ *и.* Христианнарда кабул ителгән ел исәбе. *Мөхәммәт милади белән 571 елда, ягъни моннан 1394 ел элек дөньяга килә.* Г. Гобәй.

МИЛЕК *и.* Кемгә дә булса караган һәм тулысынча аның карамагында булган мал-мөлкәт, әйберләр; байлык. *Хосусый милек.* □ *Мал тотмады, иген чәчелмәде, Милекләре бер пар тастымал.* Ш. Маннур. *— Колхоз милке ул — җәмәгать милке, изге милек, аны әрәм-шәрәм итү һич тә ярамый.* А. Шамов. || *тарт. форм. у.-вак. килеш.* **милкендә.** Карамагында, хуҗалыгында. [*Дхмәт морза*] *үз милкендәге җирләрне, урманнарны, болыннарны Казанда яңа мәчет белән мәдрәсә асрау өчен вәкыф итеп бирәчәк имеш, дигән ялган хәбәр тараттыра.* К. Нәҗми. *Ике спирт заводы һәм зур ат заводы Козырьковның милкендә иде.* Ш. Камал.

МИЛЕКЛЕ *с.* Хәлле, бай; мал-мөлкәтле. *Милекле сыйныфлар.*

МИЛЕКЧЕ *и.* Нинди дә булса хосусый милек иясе хосусый милек хуҗасы. *Горький үзе дә берәр крестьянны яздымы, аның вак милекче икәнен, милекченең дә үз милкенә нык ябышкан икәнен белдереп үтәргә ашыга.* Г. Нигъмәти.

МИЛЕКЧЕЛЕК *и.* Милектән файдалануга яки шуңа ия булуга тулы хокуклылык. *Вак милекчелеккә нигезләнгән хуҗалык.* □ *Элекке авыл агаенда хосусый милекчелек хисе тирән тамыр җәйгән, кирелек белән йомыклык та җитәрлек.* Г. Бәширов.

МИЛИТАРИЗА'ЦИЯ *и.* Империалистик дәүләтләрдә экономик, политик һәм иҗтимагый тормышны басып алу сугышы максатларына буйсындыру эше; хәрби оешмалар методын тыныч хуҗалык өлкәсендәге мөнәсәбәтләргә күчерү хәле.

МИЛИТАРИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Милитаризация үткәрү. *Илне милитаризацияләү.*

МИЛИТАРИЗМ *и.* 1. Империалистик илләрдә коралдануга, сугышка әзерләнүгә юнәлтелгән реакцион агрессив политика.

2. Империалистик илләрдә сугыш чукмарларының политик хакимлеге, илнең хуҗалыгын басып алу сугышы максатларына буйсындыру политикасы. *Икенче бөтендөнья сугышында Германия милитаризмын тар-мар итү.*

МИЛИТАРИСТ *и.* Милитаризм политикасын үткәрүче.

МИЛИТАРИ'СТИК *с.* Милитаризмга мөнәсәбәте булган. *Милитаристик политика.*

МИЛИТАРЛАШТЫРУ *ф. к.* милитаризацияләү. *Экономиканы милитарлаштыру капиталистик монополияләргә бик зур табыш бирә.* Политэкономия.

МИЛИЦИОНЕР *и.* Милиция хезмәткәре. *Кинәт урам ягында кемнеңдер кычкыру тавышы, соңыннан милиционерның сыбызгы сызгыртуы ишетелә.* Һ. Такташ. || *с. мәгъ.* Милиционерлар кия торган. *Мин урамны үткән чакта Бер ят кеше күренде: Сумка аскан, наган таккан, Милиционер киемле.* М. Җәлил.

МИЛИЦИОНЕРЛЫК *и.* Милиционер хезмәте, вазифасы.— *Нигә? Милиционерлык кечкенә эшмени? Шәһәр җирендә халыкның рәхәт яшәве, дөресен әйткәндә, милиция кулында.* М. Әмир.

МИЛИ'ЦИЯ *и.* 1. СССРда һәм кайбер башка социалистик илләрдә иҗтимагый тәртип һәм тынычлык саклау вазифасын башкара торган административ орган. *Рөстәм дә этисе белән бергә милиция идарәсенә барды.* Г. Кутуй. [*Шикле кешене*], *ачыклау өчен, милициягә тапшырдылар.* Г. Минский.

2. *сөйл.* Милиционер; милиция (1 мәгъ.) хезмәткәре.— *Милицияләр урамнан йөртмиләр, әллә кайлардан Кабан күлләре аша әйләнеп кайттым.* Т. Гыйззәт.— *Авыл советына милиция килгән, сине җиткерделәр микән әллә?* А. Әхмәт.

МИЛЛЕК *и. диал.* Мунча себеркесе, мунча яфрагы. *Былтыргы миллек белән бик каты чабынгач, юынгач, юл тузаны, ел буе җыелган кер өстән төшкән шикелле булды.* Ә. Баянов.

МИЛЛИ *с.* 1. Милләткә мөнәсәбәте булган. *Милли бәйсезлек өчен көрәш. Милли горурлык.* □ *Губерна шәһәрендә, өязләрдә, волостьларда махсус милли оешмалар төзелә икән.* И. Гази.

2. Нинди дә булса милләтнең характерлы үзенчәлекләрен чагылдыра торган; нинди дә булса милләткә хас. *Милли театр. Милли кием. Милли музыка. Милли культура.* □ *Габдулла Тукай — чын милли шагыйрь иде.* Ш. Әхмәдиев.

3. Шул илгә, дәүләткә караган. *СССРның милли флагы.* □ *Санитар поезды Москваның Александровский вокзалына килеп туктаганда, платформада халык җыелып, тынлы оркестр милли рус гимны уйнап тора иде.* М. Гали.

4. Аерым, аз санлы халыкларга караган. *Милли районнар.* □ *Изелгән милләт халыклары эксплуатация һәм милли изелүдән котылу, тигез хокук өчен көрәштеләр.* М. Җәлил.

Милли азчылык — илнең төп халкы белән чагыштырганда сан ягыннан азчылыкны тәшкил иткән милләт халкы.

МИЛЛИ- Кушма сүзләрдә икенче кисәктә күрсәтелгән төп үлчәү берәмлегенең меңнән бер өлешен белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: **миллиметр, миллиампер, миллимикрон.**

МИЛЛИАРД *сан.* 1. 1 000 000 000 ның сан һәм микъдар атамасы. *Миллиард эшче белән крестьян моннан соңра сезгә булмас коллар!* М. Гафури.

2. Бик күп, чиксез күп. *Гасырларча миллиард йөрәкләрне Чертеп килгән диннәр төрмәсен Яндырабыз! Тупка тотабыз!* Һ. Такташ. || *и. мәгъ. күпл. сөйл.* **миллиардлар.** Бик зур байлык, акча турында. *Низагларның һәммәсенең төбендә Мексика нефтеннән яңа миллиардлар хасил итү-итмәүләре мәсьәләсе ята иде.* Ф. Әмирхан.

МИЛЛИАРДЕР *и.* Акча белән исәпләгәндә миллиард һәм аннан да күбрәк сумлык байлыкка, милеккә ия булган кеше. *Инглизләрнең бөтен сәясәте — хәзер Америка миллиардерлары кулына әле тәмам әлгеп бетмәгән нефть чыгу урыннарын үз миллиардерлары кулына җыю.* Ф. Әмирхан.

МИЛЛИАРДЛАГАН *Чама саны.* Берничә миллиард; чиксез күп сандагы.

МИЛЛИАРДЛАП *Чама саны. к.* миллиард.

МИЛЛИАРДЛА'РЧА *Чама саны.* Әллә ничә миллиард; чиксез күп. *Василий җир йөзендә яшәгән миллиардларча кешеләрнең иң алдынгы вәкиле — ул коммунист.* А. Гыйләҗев.

МИЛЛИГРАММ *и.* Граммның меңнән бер өлеше.

МИЛЛИГРАММЛАП *рәв.* Миллиграмм үлчәве белән. *Миллиграммлап бүлү.*

МИЛЛИГРАММЛЫ *с.* Бер миллиграмм авырлыгындагы. *Миллиграммлы гер.*

МИЛЛИЛЕК *и.* Милли хис, милләтчелек (1 мәгъ.). — *Милләттә - - - көнлекчесе дә бар, кәвешче, читекче— һәммәсе бар. Минем башымдагы милли дигән кушамат белән миллилек булмый.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

МИЛЛИЛӘШТЕРҮ *ф.* Нәрсәгә дә булса саф милли төс бирү, милли колоритны бирергә тырышу. *Сүнчәләйнең күп тәрҗемәләрендә, бигрәк тә „Дельмансур"да, миллилəштерәм дип, асылны үзгәртүе - - - гафу ителмәскә тиеш әдәби җинаятьтер. Милләт, миллилек — бик газиз идеяләр, ләкин һәр эшнең чамасы, чиге бар.* Г. Ибраһимов.

МИЛЛИМЕТР *и.* Метрның меңнән бер өлеше.

МИЛЛИМЕ'ТРЛАП *рәв.* 1. Миллиметр озынлыгында итеп, миллиметр үлчәме белән. *Миллиметрлап бүлгәләп чыгу. Миллиметрлап исәплəү.* || *күч.* Бик аз, азлап. *Сүгү мильләп булса, баштан сыйпау — миллиметрлап.* Х. Туфан. || *күч.* Бик акрын. *Миллиметрлап кына алга бару.*

2. Микъдар саннарыннан соң килгәндә: миллиметр чамасы. *Унбиш миллиметрлап ара калдыру.*

МИЛЛИМЕ'ТРЛЫ *с.* Миллиметр үлчәмендәге. — *Коры мылтык белән агулы газларга, кырык икешәр миллиметрлы пушкаларга каршы торып булмый шул.* Т. Гыйззәт. || Миллиметрларга бүленгән. *Миллиметрлы линейка.*

Миллиметрлы кәгазь — шакмаклары бер квадрат миллиметрга тигез булган сызым кәгазе.

МИЛЛИМЕТРО'ВКА *и. сөйл. к.* миллиметрлы кәгазь.

МИЛЛИОН *сан.* 1. 1 000 000 ның сан һәм микъдар атамасы. *Ул илләрдә эшсез калган эшче Унар миллион белән санала.* М. Гафури.— *Әлфия, колхозның доходын миллионга җиткердеңме инде? — дип, Газинур өстәл янына атлады.* Г. Әпсәләмов. || *каб. форм.* Бик күп миллион.— *Сезнең һәм сезнең кебек миллион-миллион Марат, Санҗя, Илдарларның якты көннәрен караңгы төн итәргә килгән Гитлер яуларын тар-мар иткәндә үлде әтиегез.* Г. Гобәй.

2. Бик күп, чиксез күп; миллионлаган. *Бу бүләктә мең-мең йөрәк җыры, Миллион күңелләрнең җылысы.* Ә. Фәйзи. *Төннәрендә яна миллион утлар, Сүнмәс маяк булып яктырып.* Ә. Исхак. || *и. мәгъ. күпл. сөйл.* **миллионнар.** Бик зур байлык, акча турында. *Әтидән калган миллионнар бар да китте далага, Әти хәзер күрсә әйтер иде: „Ни булды бу балага?"* Ш. Мөхәммәдев. || Шундый ук кулланышта: әллә ничә миллион кеше, бик күп халык. *Тугызынчы май төнендә яңгыраган радио тавышына миллионнар белән*

бергә әминә дә уянды. Г. Минский. *Тынычлык — миллионнар сүзе, Ил имин дигән сүз ул.* З. Мансур.

МИЛЛИОНЕР *и.* 1. Акча белән исәпләгәндә миллион һәм аннан да күбрәк сумлык байлыкка, милеккә ия булган кеше. *Миллионерлар бөләләр, әйбер хакын күтәргә Малны суга түгәләр.* Н. Исәнбәт. *— Миллионер Садыйк хаҗины сез беләсез бит? Беләсез. Татар байлары арасында иң карагруһ, контр әфләтун ул.* К. Тинчурин.

2. Табышы миллион яки миллионлаган сум белән исәпләнә торган колхоз турында.— *Нәсимә кызым, безнең „Уңыш" быел да миллионер булыр микән?* А. Әхмәт.

3. Миллион яки миллионлаган километр очкан очучы турында.

МИЛЛИОНЕРЛЫК *и.* Миллионер булу хәле. *Хасиятулла бабай --- [үз] колхозын СССР күләмендә иң алдынгы колхозлар сафына, миллионерлык дәрәҗәсенә җиткерү турында уйланып ләззәтләнә иде.* Ш. Камал.

МИЛЛИОНЛАГАН *Чама саны.* Берничә миллион, чиксез күп сандагы. *Социализм чоры илебезнең миллионлаган хезмәт ияләре алдында --- аңлы хезмәт дисциплинасын тудырды.* М. Җәлил. *Сәгъдәт апаларның бу тормышы — миллионлаган әшчеләрнең тормышыннан уртача бер үрнәк.* Ф. Кәрим.

МИЛЛИОНЛАП *Чама саны. к.* миллион. *Бу күпер буена дошманның миллионлап бомбасы, снаряды, минасы төшкән, ләкин аларның берсе дә соңгы көнгә чаклы күперне җимерә алмаганнар.* Х. Мөҗәй.

МИЛЛИОНЛЫ *с.* Миллионны әченә алган. *Миллионлы гаскәр туплау.*

МИЛЛИОННА'РЧА *Чама саны.* Әллә ничә миллион; чиксез күп. *Миллионнарча халык, урамнарга чыгып, Актык кайнар сәламнәрен Ильичына сөйләде.* Г. Кутуй. *Алда аны, мине, безнең кебек --- миллионнарча егетләрне нәрсә көтә?* Г. Ибраһимов.

МИЛЛИОНЫНЧЫ *Тәрт. саны. к.* миллион.

МИЛЛӘТ *и.* 1. Кешеләрнең тел, территория, экономик тормыш, психик үзенчәлекләр һәм культура уртаклыгы нигезендә барлыкка килгән тотрыклы зур коллективы; шундый уртак сыйфатлар нигезендә бергә берләшкән, тупланган халык. *Без икебез ике милләт улы, Безне тапкан төрле аналар. Берләштерде безне тормыш юлы, Дуслык белән якын аралар.* Н. Дәүли. *Сугыш төрле милләтләрне бер-берсенә тагын да якынайтты.* А. Әхмәт.

2. Дәүләт, ил. *Берләшкән милләтләр оешмасы.*

Милләтләр лигасы — халыкара конфликтларны тыныч юл белән хәл итү өчен төзелгән халыкара оешма (1919 елда төзелеп, 1946 елга кадәр яши).

МИЛЛӘ'ТАРА *и.* Милләтләр арасында бара торган, яши торган; күп милләтләргә карый торган. *Милләтара мөнәсәбәтләр. Милләтара аралашу теле.*

МИЛЛӘТТӘШ *с.* 1. Бер милләттән булган. *Шәһәри Казанны, милләттәш туганнарымны ирексездән иңрәп сагынган чакларым була.* Ә. Еники.

2. *и.* Кем белән дә булса бер милләттән булган кеше. *Түзә алмадым, бардым җырлаучыга, Дидем: „Кардәш, бу көй — нинди көй?" Җавабында милләттәшем миңа: „Бу көй була, диде, әллүки!"* Г. Тукай.

МИЛЛӘТЧЕ *и.* 1. Милләтчелек (1 мәгъ.) тарафдары. *Сыйнфый көрәш кискенләште. Милләтчеләрнең, солтангалиевчеләрнең контрреволюцион йөзләре тагын бер кат ачык күренде.* Х. Госман. *Камал үзенең көчле сатирик әсәрләре белән татар буржуа милләтчеләрен һәм руханиларын аяусыз фаш итте.* М. Җәлил.

2. Милли азатлык хәрәкәтен яклаучы, шул хәрәкәттә катнашучы.— *Безнең арада чын ихласлы милләтчеләр тиз генә туачак та түгел. Чөнки без барыбыз да кол, дәрвиш!* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Төрек милләтчеләре үзләренең бүгенге юлларын Россия Советлар власте юлы белән бергә күрәләр.* Ф. Әмирхан.

МИЛЛӘТЧЕЛ *с.* Милләтчелеккә (1 мәгъ.) хас. *Милләтчел караш.* || *рәв. мәгъ.* Милләтчеләргә (1 мәгъ.) хас булганча. *Бу да шулай ук милли тел мәсьәләсен буржуача, милләтчел аңлау булып, милли форма сылтавы белән прогрессив эчтәлекне инкяр итүдән гыйбарәт иде.* Г. Халит.

МИЛЛӘТЧЕЛЕК *и.* 1. Милли өстенлекне, бер милләтне зурлап, икенчесен кимсетеп карауны яклый торган реакцион буржуаз идеология. *Революциягә кадәрге татар әдәбиятының реакцион катлавын тәшкил иткән язучылар өчен тар милләтчелек, пантюркистлык --- характерлы булып калды.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Шундый идеология белән сугарылган. *Милләтчелек карашы.* □ *Мохтар Гайфуллинның --- милләтчелек рухында сөйләгән речьләрен ишеткәләгәне бар иде.* Ш. Камал. || Милләтчелеккә мөнәсәбәте булган. *Милләтчелек политикасы.* □ *Буржуаз милләтчелек хәрәкәтенең һәм аның оешмаларының сыйнфый йөзен һәрвакыт фаш итеп торырга кирәк иде.* Г. Ибраһимов.

2. Буйсындырылган илләрдә империализмга, колониализмга каршы милли бәйсезлек өчен көрәш хәрәкәте. *Без, проблемага Ленинча килеп, изелүче милләтләрнең милләтчелеге белән изүче милләтләрнең агрессив шовинизмын бер-берсеннән аера белергә тиешбез.* М. Госманов. *Мостафа Кәмал паша хәрәкәте --- чын милли, чын халык хәрәкәтедер. Менә шул хәрәкәт, менә шул төрек милләтчелеге бүген Россия Советлар властена дуслык, кардәшлек кулын суза.* Ф. Әмирхан.

МИЛЬ *и.* Төрле илләрдә төрлечә кулланыла торган озынлык үлчәү берәмлеге. *Коры җир миле* (1609 метрга тигез). *Диңгез миле* (1852 метрга тигез). □ *Артыбызда бер мең мильгә якын диңгез киңлекләре калды.* Р. Мостафин.

МИЛӘШ *и.* 1. Роза чәчәкләләр семьялыгыннан тәлгәшле, гадәттә саргылт кызыл җимешләре булган агач яки биек булып үсә торган куак. *Печән өсте матур чак, миләш чәчәк атар чак.* Җыр.

2. Шул агачның җимеше. *Фәрит Мараткә үз бакчаларыннан миләшне тәлгәше белән өзеп алып бирде.* Г. Гобәй. *Секретарьның чырае инде төче түгел, ничектер миләш чәйнәгән кеше чыраена охшый төшкән иде.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Шул җимештән хәзерләнгән. *Миләш кагы. Миләш төнәтмәсе. Миләш вареньесы.*

Миләш елы — миләш уңган ел. *Миләш бик гайрәтле басып тора, әйтерсең лә койма буена сакка куйганнар! Эре тәлгәшләре салкын ут сыман. Миләш елы бугай быел.* Б. Камалов. **Миләш чыпчыгы** — урманда яшәүче зур булмаган сайрар кош. [*Миләш*] *җимешләре белән бөҗырлар, миләш чыпчыклары сыйланалар.* М. Рафиков. **Миләш төсе** — саргылт кызыл төс. *Су буендагы әрәмәләр белән урманнар башта саргайды, урыны-урыны белән кызарды, миләш төсенә керде.* Г. Бәширов. **Миләш борын** — кечкенә кызыл борын.— *Әле син шулай шүрәледән курыкмыйсың, ә? — Курыкмыйм шул! — Кара, кара син аны, нәрсә ди бит ул, миләш борын.* Д. Аппакова.

МИЛӘШЛЕК *и.* Миләш агачлары яки куаклары күп үсә торган урын. [*Курайлы елганың*] *яр буйлары --- миләшлекләр, баланлыклар, тагын бик күп шундый куаклыклар белән капланган.* Г. Галиев. *Өй арты — миләшлек. Кып-кызыл, кып-кызыл.* Н. Исәнбәт.

МИЛӘҮШӘ *и.* Шәмәхә, сирәгрәк, сары яки төрле төсләрдәге чәчәкле үлән үсемлек. *Бирәм инде сиңа чәчәкләр, Миләүшәмә кирәк, башкасымы...* Ф. Бурнаш. *Түтәлне тутырып үсә җиләкләр, Нәркис, миләүшә, сөмбел һәм мәкләр.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Шәмәхә төсле. *Офык читендә миләүшә болытлар сузылып киткән.* Р. Мостафин.

Миләүшә гөл — *к.* миләүшә. *Урманда үткән елгы яфраклар астыннан миләүшә гөленең тәмле исле кечкенә генә чәчәкләре башларын калкытып киләләр.* С. Җәләл. **Миләүшә төс** — шәмәхә төс. *Кияү бүлмәсе ак, кызыл, кара, яшел, саргылт, зәңгәр, күгелҗемкара, сыек миләүшә төсләре дулкыны эченә батты.* Г. Ибраһимов.

МИ'МИК I *и.* Мимикага (1 мәгъ.) оста артист. *Шәйхзадә — гаять көчле мимик, артист.* Н. Исәнбәт.

МИ'МИК II *с.* Мимикага мөнәсәбәте булган. *Мимик хәрәкәтләр ясау. Мимик сәнгать.*

МИ'МИКА *и.* 1. Хис, рухи халәтне чагылдыра торган йөз мускуллары хәрәкәте.— *Шәрәфиевнең күзендә генә нинди утлар бар, син кара аның мимикасына, [ничек] тиз төсен алмаштыра.* Г. Газиз.

2. Йөз мускуллары хәрәкәтләре белән хисләрне, рухи халәтне чагылдыра алу сәнгате. *Артист өчен йөз мимикасының нинди зур әһәмияткә ия булуын һәркем белә. Ә бит сәхнәдә уйнаган һәр образның үз мимикасы бар.* Каз. утл.

МИМИКРИ'Я *и. биол.* Кайбер хайваннарның һәм үсемлекләрнең, саклану, яшәү өчен көрәш чарасы буларак, тышкы формалары һәм төсләре белән табигать чолганышына яки башка хайваннарга һәм үсемлекләргә охшашлыгы. *Табигатьтә организмнарның тереклек шартларына бик күп төрле җайланмалары була. --- Аларга саклагыч төс һәм мимикрия күренешләре керә.* Биология. || *күч.* Иҗтимагый тормышка бернинди принципсыз җайлашу.

МИМО'ЗА *и. бот.* 1. Кузаклылар семьялыгына керә торган тропик үсемлек (агач, куак, лиана); кайбер төрләренең яфраклары аз гына кагылу белән йомарланып китәләр.

2. Мәңге яшел һәм вак, сары себерке чәчәкле акация төре. *Мимозалар да чәчәк атып, диңгезнең кырые сап-сары чәчәк белән тулды.* Г. Газиз. *Кулында аның суланган Мимоза букетлары.* М. Җәлил.

МИМЫЛДАТУ *ф. сөйл.* 1. Селкетү, хәрәкәтләндерү (симез тән мускуллары турында).

2. Бер ачып, бер йомып хәрәкәтләндереп, селкетеп тору (иреннәр, күзләр турында). *Актырнак, койрыгын бутап, күзләрен мимылдатып, дусларча гына кызыл сыерның алдына туктады.* М. Гафури. *Авызын-күзен мимылдатып карап тора әбкәсе.* Җыр.

МИМЫЛДАУ *ф. сөйл.* 1. Селкенеп, хәрәкәтләнеп тору (симез тән мускуллары турында).

2. Бер ачылып, бер йомылып, селкенеп, хәрәкәтләнеп тору (иреннәр, күзләр турында).

МИМЫЛДЫК *с.* Мимылдап (1 мәгъ.) торган. *Миңсылу мимылдык гәүдәле, кара чәчле бер хатын иде.* Ф. Әмирхан. [*Аграфена түти*] *бераз карап торды да егетне мимылдык күкрәгенә кысып алды.* И. Гази.

МИН (минем, миңа, мине, миннән, миндә) *а.* 1. Сөйләүченең үз-үзен күрсәтүе, атавы өчен кулланыла. *Мин чит авыллар һәм чит шәһәрләр аша узам. Җиңү мине Берлинга алып бара.* Г. Кутуй. *Әндәшә батыр утынчы: „Сиңа миннән ни кирәк?"* Г. Тукай.

2. Шәхес, индивидуум буларак үз-үзеңне атау, үзеңнең барлыгыңны, яшәешеңне, шулай ук (философиядә) субъектыңны белдерү өчен кулланыла. *„Мин!" дидем мин, яшәсен „мин!" „Мин" минемчән алла ул, Рухым үлгәндә күренсә, Рухыма җан салган ул.* С. Рәмиев.— *Мин мин идем, моннан соң да мин булып калырмын.* М. Фәйзи.

◇ **Мин сиңа әйтим** — сөйләмнең эмоциональлеген арттыру, тыңлаучының игътибарын җәлеп итү өчен кулланыла.— *Безнең әлеге кодача дигән нәрсә бәла булды тагын! Килеп-килеп, мин сиңа әйтим, йоннарыбызны тетә.* Ш. Камал. **Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче генә эшләү** — аннан-моннан, өстән-өстән генә, начар сыйфатлы итеп эшләү. **Миңа димәгәе, миңа дисә(ләр)** — үпкәләп, ачуланып, берәр хәлгә искитмәүчәнлек мөнәсәбәте белдерү өчен кулланыла. *—Мин хәзер үк районга шалтыратам, моны болай калдырырга ярамый.— Шалтыратыгыз! Миңа димәгәе!* Н. Фәттах.— *Миңа дисәләр, кырык чөйләре кырылып бетсен шунда. Хәбибрахман абыйларның да, Гафифә апаларның да театрга киткәннәрен әйтәм.* Г. Камал.

МИ'НА *и.* 1. Җиргә күмеп яисә суга батырып куела торган шартлагыч снаряд. *Гитлерчылар, безнең һөҗүмне туктатырга теләп, контратакаларга ташланып карадылар, авылларга керү юлларына миналар куйдылар.* Каз. утл.— [*Немец минерларыннан*] *үзләре куйган миналарны казытып алыгыз. Безнең гаскәрләргә, танкларга юл ачылсын.* С. Баттал.

2. Миномет снаряды. *Дошман елга аркылы үзенең туп-минометларыннан авыл өстенә снарядларны, миналарны яудырып кына тора.* Ә. Айдар. *Яктыртkыч пуляләр өере Мисбахның баш очыннан выжлап узды. Шуның артыннан ук миналар төшеп ярыла башлады.* Г. Әпсәләмов.

3. *к.* торпеда.

Мина кыры — миналар куелган урын, мәйдан; шулай ук диңгездә, күлдә бер яки берничә рәт миналар киртәсе (загражденисе) корылган район. *Алда, астарак, елга бозы, ә аның арьягында дошманның мина кыры иде.* И. Гази.

МИ'НАЛАУ *ф.* Мина(лар) салу, кую. *Немецлар тирә-юньне миналаганнар, саперлар хәзер шуны арчып яталар.* Г. Бакиров.

МИ'НАЛАШТЫРУ *ф. к.* миналау. *Рөстәм, миналаштырылган сукмакларга яки кырларга әләкмәс өчен, саклана-саклана юлның уртасыннан барды.* Г. Кутуй. *Совет командованиесе [реактив минометлы] һәр машинаны миналаштырырга приказ бирә.* Каз. утл.

МИ'НАЛЫ *с.* Миналанган, миналар куелган. *Без окопларны, аннан миналы уйсулыкны гадәттәгечә тын гына үттек тә авылга таба юнәлдек.* А. Расих.

МИ'НАСЫЗЛАНДЫРУ *ф. к.* минасызлау.

МИ'НАСЫЗЛАУ *ф.* Миналанган урынны миналардан арындыру.

МИ'НАЧЫ *и.* Урыннарны яки бәрәр төрле объектларны миналау яки минасызландыру, шулай ук дошман ныгытмаларын шартлату өчен җир астыннан казып керү эшләрен башкаручы белгеч.

МИНБЕЛӘМЛЕК *и. сөйл. ирон.* „Мин күп беләм" дип дәгъва итүче кешенең үз-үзен тоту манерасы, холкы турында. *Бу мидә бардыр җәһәләт ун вагон, „Минбеләмлек" дәгъвасы — бер мең вагон.* Г. Тукай. *Җәүдәт үтә мактанчык, „Минбеләмлек" — йөз капчык.* Ә. Фәйзи.

МИНДАЛЬ *и.* 1. Роза чәчәкләләр семьялыгыннан чикләвек сыман җимешле, көньякта үсә торган агач яки куак. *Күкрәп үсә тирә-юньдә Миндаль, сәрви.* К. Нәҗми.

2. Шул агачның җимеше — чикләвеге. || Шул җимешнең ачы яки төчерәк тәмле төше. *Миндаль сибеп әзерләнгән торт.*

3. *сөйл. к.* миндальсыман биз. *Миндальләрне кистеру.*

МИНДАЛЬЛЕ *с.* Миндаль кушып, миндаль катнаштырып әзерләнгән. *Миндальле пылау.*

МИНДАЛЬСЫМАН: миндальсыман биз — йоткылыкта була торган миндаль чикләвегенә охшашлы биз.

МИНЕКЕ *тарт. а.* **1.** Кемнең яки нәрсәнеңдер беренче зат исеменнән сөйләүчегә караган булуын белдерә. *Дөньяда бар су минеке, Бар кара җир минеке, Бар тау, урман, бар матур кош — Барысы да минеке.* С. Рәмиев.

2. *и. мәгъ. сөйл. әвф.* Ир, сөйгән яр турында. || *күпл.* **минекеләр.** Сөйләүче кешенең гаиләсе, балалары, якыннары, туганнары. [*Муса Арысланга:*] *Минекеләргә хат язып сал. Тиздән күрешербез, диген.* Ш. Маннур.

МИНЕ'МЧӘ *рәв.* **1.** Мин әйткәнчә, мин уйлаганча. *Нәфисәнең тәне эсселе-суыклы булып китә. Күңеленә бере артыннан бере мең төрле шик килә. --- „Юк, юк! — диде ул. — Минемчә булыр, мин әйткәнчә".* Г. Бәширов.

2. Мин кушканча, мин өйрәткәнчә. *Минемчә эшләсәң, уңарсың.* Сов. әд.

3. *кер. сүз. функ.* Сөйләүченең үз фикеренә, үз тәжрибәсенә таянып сөйләвен белдерә.— *Минемчә, сиң урынсыз шатланасың. Мин хәзер генә ишеткән хәбәрдә бер дә шатланырлык урын тапмыйм.* Ш. Усманов.

МИНЁР *и.* **1.** *к.* миначы. *Әнә тагын кемнәрнедер тотып алып киләләр. Алары минерлар икән.* С. Баттал. *Минер эшенең шундый дәһшәтле икәнлеген кем уйлаган.* Г. Әпсәләмов.

2. Хәрби корабта миналы коралларга хезмәт күрсәтүче белгеч.

МИНЕРАЛ *и.* Җир кабыгы составында булган табигый химик кушылма яки каты, сыек, газсыман хәлдәге элемент. *Фәнгә өч меңгә якын минерал билгеле.* Каз. утл. *Шаулап үсә байлык җир өстендә, Байлык чыга җирнең төбеннән: Күмер, битум, торф, нефтеносларМинераллар һәрбер төреннән.* Ә. Исхак.

МИНЕРАЛЛАУ *ф.* Минераль тозлар белән туендыру. *Кальций тозы белән минералланган чыганаклар.*

МИНЕРАЛЛАШУ *ф.* **1.** Органик матдәләрнең минералларга, минераль кушылмаларга әйләнүе.

2. Минераль тозлар белән туену яки туенган булу. *Туфракның минераллашу процессы. Суның минераллашу дәрәҗәсе.*

МИНЕРАЛЛЫ *с. к.* минераль. *Минераллы су.*

МИНЕРАЛО'Г *и.* Минералогия белгече.

МИНЕРАЛО'ГИК *с.* Минералогиягә мөнәсәбәте булган. *Минералогик тикшеренүләр. Минералогик үрнәкләр.*

МИНЕРАЛО'ГИЯ *и.* Минераллар турындагы фән. *Минералогия профессоры. Халыкара минералогия конгрессы.*

МИНЕРАЛЬ *с.* Минераллардан торган. *Минераль матдәләр. Минераль ашламалар. Минераль ягулыклар.* || Составында минераллар булган. *Минераль чыганак.* □ *Катя бер стакан кайнар минераль су агызып алды.* И. Гази.

МИНЁРЛЫК *и.* Минер хезмәте. *Минерлыкка өйрәнү.*

МИНИАТЮР *с.* **1.** Миниатюрага (1, 2 мәгъ.) мөнәсәбәте булган. *Миниатюр хәреф. Миниатюр картиналар.*

2. Бик кечкенә, кечкенә күләмле. *Миниатюр диктант.* □ *Бу җайланма үзенә күрә бер миниатюр станокны хәтерләтә.* Каз. утл. || Кечкенә һәм нәфис.— *Ничек инде шундый сөйкемле һәм көлемсерәп карап торган миниатюр хатыннарны кошлар шикелле иректә йөртмәскә кирәк.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

МИНИАТЮ'РА *и. кит.* **1.** Кечкенә күләмле буяулы рәсем яки иске кулъязмада, китапта бизәкләп язылган баш хәреф.

2. Оста һәм нәфис ясалган кечкенә картина яки портрет. *Каршыдагы стенада матур кысалы Репин рәсеме --- эленгән. Болардан башка тагын миниатюрада бирелгән табигать күренешләре дә күп кенә иде.* Г. Бәширов.

3. Кечкенә күләмле әдәби яки музыкаль әсәр. *Миниатюралар театры.* □ *Ибраһим ага Газины без роман, повесть һәм хикәяләр авторы буларак беләбез. Баксаң, аның күңел дәфтәрендә әнҗе бөртекләредәй миниатюралар да бар икән.* Б. Камалов.

МИНИАТЮРЧЫ *и.* Миниатюралар ясаучы рәссам.

МИНИМАЛИЗМ *и.* Таләпләрне иң түбән чиккә төшерү, минимумга калдыру.

МИНИМАЛИСТ *и.* Минимализм тарафдары.

МИНИМАЛИ'СТИК *с.* Минимализмга нигезләнгән. *Минималистик политика.*

МИНИМАЛЬ *с.* Башкалар рәтендә иң аз, иң кечкенә; *киресе:* максималь. *Минималь ераклык. Минималь таләпләр.*

МИ'НИМУМ *и.* **1.** Иң кечкенә микъдар; *киресе:* максимум. *Кашшаф --- хисапчыдан хезмәт көне минимумын үтәмәүчеләрнең исемлеген сорап алды.* Р. Төхфәтуллин. *Пушкин белән Толстойны белмәү --- безнең заман яшьләре өчен зур кимчелек саналырга мөмкин. Безнең шартларда Г. Тукай белән Г. Ибраһимов та шундый ук минимумга кермиме икән?* Г. Бәширов.

2. Нинди дә булса өлкәдә кирәк булган белемнәр яки планлаштырылган эшләр җыелмасы. *Техник минимумнар.* □ *Менә минимумны тапшырырга да әкренләп кандидатлык диссертациясе турында уйлый башларга кирәк.* Ф. Хөсни.

3. *рәв. мәгъ.* Иң азы, аз дигәндә.

МИНИСТР *и.* Министрлык белән җитәкчелек итүче дәүләт вәкиле. *Министрлар Советы. Мәгариф министры.* □ *Ике көн эчендә патшаны бөтен министрлары белән ыргытыктан ташладык.* К. Нәҗми.

МИНИ'СТРЛАРЧА *рәв. сөйл. ирон.* Министрлар кебек, бик югарыдан, эре генә.

МИНИСТРЛЫК *и.* **1.** Дәүләт идарәсенең аерым тармагы белән җитәкчелек итә торган үзәк хөкүмәт учреждениесе; шул учреждение урнашкан бина. *Авыл хуҗалыгы министрлыгы. Культура министрлыгы.* □ *Мәскәүдән китәр алдыннан Мортазинны Үзәк Комитетка һәм министрлыкка чакырдылар.* Г. Әпсәләмов.

2. Хөкүмәт, буржуаз парламентаризм системасында шул хөкүмәтнең министрлар составы. *Министрлыклар алмашыну.*

3. Министр вазифасы, хезмәте. *Министрлыкка сайлау.*

МИН-МИНЛЕ *с.* һавалы, тәкәббер, масаючан. *Гәрәй дә шактый усал, шактый мин-минле малай шул.* К. Басыйров.

МИН-МИНЛЕК *и.* **1.** Масаючанлык, һавалылык; тәкәбберлек. *Мин-минлек башка җитәр.* Мәкаль. *Әллә аның --- мин-минлеген авызлыклый торган өстен бер көч бармы Борисовның күңелендә?!* А. Гыйләҗев.

2. Үз көченә, сәләтенә тиешеннән артык бәя бирү, үз-үзенә сукырларча ышанучанлык. *Аның эчендә „мин-минлек" дигән Бер чиксез юньсез шайтан бар икән.* Х. Туфан. *Ул соңгы вакытларда Шәрифуллинның*

кирәгеннән артык мин-минлек сыйфатларының гомуми эшкә зарар китерүен газапланып уеннан кичерде. С. Рафиков.

МИН-МИНЛЕКЛЕ *с.* 1. Масаючан, мактанчык; тәкәббер.

2. Үзбелдекле, үз көченә, сәләтенә сукырларча ышанучан.

МИН-МИНЛӘНҮ *ф. сир.* 1. Масаю, үз-үзен әре, һавалы тоту; тәкәбберләнү. *Дәүли үзе дә һәрвакыт үзен-үзе күрсәтергә, мин-минләнергә, үзеннән башканы кешегә санамаска бик ярата.* М. Гали.

2. Үз көченә, сәләтенә тиешеннән артык бәя бирү, үз-үзенә сукырларча ышану. *Мин-минләнгән егетне яу килгәндә күрербез.* Мәкаль.

МИН-МИНСЕНҮ *ф. сир. к.* мин-минләнү. *Ажгырган айгырның өерен күр, мин-минсенгән егетнең өен күр.* Мәкаль.

МИН-МИНЧЕЛ *с. к.* мин-минлекле 1.

МИННӘТ *и. иск. кит.* 1. Берәүгә иткән нинди дә булса яхшылыгын, ярдәмен һаман искә төшереп тору, шуның белән битәрләү.— [*Сезнең*] *әллә нинди җаһил, зур корсаклы байларның миннәтен ишетмичә көн итәсегез, гомер уздырасыгыз килә башлар.* Ф. Әмирхан. *Миннәт белән коймак ашаудан миннәтсез таяк ашау яхшырак.* Мәкаль.

2. Асралуы, яшәве өчен бурычлылык. *Агачтыр аты, Тимердән каты, Ил өстендә миннәте, Су өстендә кодрәте.* Табышмак.

3. Яхшылыкка каршы яхшылык белән җавап бирү, шатлык, рәхмәт белдерү хәле. *Һәр һиммәтнең миннәте бар.* Мәкаль.

Миннәт итү (кылу) — эшләгән яхшылыгын һәрвакыт искә төшереп тору һәм үзенә дә шуны таләп итү. *Мөрәүвәтсез җаһилләргә юлдаш булсаң, Аз гына нәрсәсенә кыйлыр миннәт.* М. Гафури.

МИННӘТДАР *с. иск. кит. к.* миннәтле. *Мин дөньяда вакытымда* [*„Вакыт“ мөхәррирена ярдәмнәр*] *иткән идем. Ул миңа миннәтдар иде.* Г. Тукай.

МИННӘТДАРЛЫК *и. иск. кит.* Рәхмәт әйтү, канәгатьлек белдерү хәле. *Татар дип тә мондагы егетжиләнгә --- бик үк миннәтдарлык булыну тиеш түгеллеген аңлатыр өчен бу сүзне әйтте* [*карчык кызына*]. Ш. Камал.

МИННӘТЛЕ *с. кит.* Күргән яхшылык, ярдәм яки берәр эш-хәл өчен шатлык, рәхмәт белдерүче; берәүнең яхшылыгы, ярдәме астында булуны танучы.

МИННӘТЛЕК *и. кит. к.* миннәт 1. *Һиммәтле кешедә миннәтлек юк.* Мәкаль.

МИННӘТЛЕЛЕК *и. кит.* Миннәтле булу; миннәтле булу сыйфаты.

МИННӘТСЕЗ *с. кит.* Ярдәмгә каршы ярдәм, яхшылыкка каршы яхшылык таләп итүгә корылмаган. — *Без бу дөньяда шундый дус булдык, эчебез керсез, сый-хөрмәтебез миннәтсез булды.* З. Бәширн.

МИННӘТЧЕЛ *с. кит.* Ярдәмгә каршы ярдәм, яхшылыкка каршы яхшылык алырга яратучан, таләп итүчән.— *Мин сезнең миннәтчел кешеләр түгел икәнлегегезгә бик нык ышанам.* С. Кудаш.

МИНОГА *и. зоол.* Түгәрәк авызлылар семьялыгыннан суалчан сыман яки шәрә елан сыман гәүдәле, балыкка охшашлы су җәнлеге.

МИНОМЁТ *и.* Миналар ата торган корал, тәгәрмәчсез туп. *Күбрәк танк, туплар, гранаталар, Минометлар кирәк фронтка.* М. Җәлил. *Немец --- я артиллериядән, я миномёттан өзлексез атып тора.* И. Гази.

МИНОМЁТЧЫ *и.* Миномет частенда хезмәт итүче гаскәри; минометтан атучы. *Авыр сугыш юллары үткән миномётчылардан берәү әле кичә генә өйдән килгән хатны укып күрсәтә.* Г. Бакиров.

МИНОНОСЕЦ *и.* Торпедалар белән коралланган хәрби корабль. *Брандус сугыш мәйданына дошман миноносецы белән бик тиз йөрешле катерлар якынлашуын хәбәр итте.* Г. Әпсәләмов.

МИНОР *и. муз.* Тавышлары кече терцияле аккорд барлыкка китерә торган музыкаль лад (кайгылы, төшенке тавыш төсмерләре белән характерлана); *киресе:* мажор.

МИНОРЛЫ *с.* Минор авазлар тезмәсенә нигезләнгән. *Минорлы гамма. Минорлы аккорд.*

МИНСЕНҮ *ф. сир. к.* мин-минләнү. *Минсенгән— мин, мин дип күкрәк каккан.* Мәкаль. *Ул ни өчендер, тиктомалдан үзалдына һаваланып китеп, минсенергә тотынган.* Н. Исәнбәт.

МИНУС *и.* 1. *мат.* Алу гамәлен яки кире зурлыкны белдерә торган билге (—).

2. Ике сан арасында икенчесенең беренчесеннән алынуын (киметелүен) күрсәтү өчен кулланыла. *Җиде минус өч тигез дүрткә.*

3. Кире зурлык *(мат.)* || Нульдән түбән булган температураны күрсәтү өчен кулланыла. *Бүген һаваның температурасы минус 17 градус.*

4. *күч.* Кире як, кимчелек.— *Без барыбыз да заман продукциясе. Үзебездә заманның плюсларын һәм минусларын йөртәбез.* Г. Ахунов.

МИНУСЛЫ *с.* Нульдән түбән (һава температурасы турында).

МИНУТ *и.* 1. Сәгатьнең 1/60 өлешенә тигез һәм 60 секундтан торган вакыт үлчәү берәмлеге. *Бер минут эчендә бөтен күл өсте малайлар белән тулды.* И. Гази. *Секундлар минут, ә минутлар сәгать булып тоелдылар.* Ә. Айдар.

2. Бик кыска вакыт арасы, мизгел. *Кадерле минутлар. Куркынычлы минутлар якынлашу.* □ *Нишлим, нишлим, соңгы минутымда Пистолетым итте хыянәт.* М. Җәлил. *Фикер җебе, бер вакыйгадан икенчесенә сузылып, йөрәккә сеңеп калган аерылу минутларына килеп тоташты.* И. Гази.

3. *махс.* Градусның 1/60 өлешенә тигез булган һәм язуда цифрның өске уң ягында махсус билге (′билгесе) белән күрсәтелә торган почмак яки дуга үлчәү берәмлеге.

◇ **Минуты-сәгате (секунды) белән** — шунда ук, бик тиз арада. *Гафиятулла бабайның кунак кызлар турындагы хәбәре минуты-сәгате белән бөтен колхозга таралды.* Г. Әпсәләмов. *Әлбәттә, минуты-секунды белән сүз башлап, кызган ташка су сибеп сикертергә ярамас.* Ф. Хөсни. **Минутка-минут** — бик төгәл, нәкъ билгеләнгән вакытта. **Минутлар белән яшәү** — хәзерге көн белән генә яшәү, киләчәк турында уйламау.

МИНУТЛАП *рәв.* 1. Минут исәбе белән; минут үткән саен. *Сугыш кешеләрне еллап түгел, сәгатьләп, минутлап картайтты.* Н. Дәүли.

2. Микъдар саннарыннан соң килгәндә: минут чамасы. *Егерме минутлап вакыт үтү.*

МИНУТЛЫ *с.* Минут эчендә башкарыла торган, минут эчендә булып уза торган. *Минутлы күренеш.*

МИНУТЛЫК *с.* Минут эчендә башкарылган. *Балкондагы биш минутлык сәяхәтем --- җанга авыр булып йөри торган хисләрне җуйды.* Ф. Әмирхан. || *күч.* Бик кыска вакыт эчендә, бик тиз башкарыла торган.— *Игъланны капкага ябыштыру — минутлык эш.* С. Рафиков. *Синең алай --- минутлык шашынуга бирелергә хакың бармы соң?* Р. Төхфәтуллин.

МИНЧЕЛ *с. к.* мин-минчел. *Көнчел кеше — минчел кеше.* Мәкаль.

МИНЧЕЛЕК *и. к.* мин-минлек. *Электән килгәннең бөтенесең тоташтан җимерү, социалистик революциянең иҗади асылын күреп җиткермәү, барлык нәрсәгә аермасыз гыйсъян итү, минчелек — вак буржуаз революционлык тәэсире күбрәк әнә шуларда гәүдәләнде.* Х. Госман.

МИОКАРДИТ *и. мед.* Йөрәк мускуллары авыруы.

МИР *и. сөйл.* Авыл халкы, авыл җәмәгатьчелеге. *Мир өендә күптән җыелыш бара.* Н. Баян.— *Ник җыен җыймыйсың? Хәбәрнең дөресен ник мирдән яшерәсең?* М. Галәү. || Күп кеше, халык. *Мир төкерсә күл була.* Мәкаль.

МИРАБЕЛЬ *и. бот.* 1. Җимеш агачы, сливаның бер төре.

2. Шул агачның вак сары җимеше.

МИРАЖ *и.* 1. Атмосфераның төрле катлаулары төрле дәрәҗәдә җылыну нәтиҗәсендә ачык һәм тын һавада була торган күренеш (бу вакытта горизонт артындагы күренми торган әйберләр һавада чагылып күренәләр); сагым. *Шадра диңгез өсте, кипарислар, Тезелеп киткән йөзем түтәле — Мираж төсле күзгә чагылып үтте Иртәнге ак томан үтәли.* М. Җәлил. *Чыннан да, бу нинди тылсымлы күренеш соң? Бәлкем, бу бары мираж — күз алдануы гынадыр.* И. Салахов.

2. *күч.* Хыял; анда, хыялда тудырылган нәрсә. [*Ида аңарда*] *үзе уйлап тапкан --- әллә нинди яхшы сыйфатларның бары тик мираж гына, декорация генә булганлыгын аңлады.* Н. Фәттах. *Ул --- бөтен бу сөйләгән, уйлаган, хәтта хис итеп уздырган нәрсәләрнең чын түгел, хыял гына, мираж гына икәнен тойган шикелле булып китте.* Ф. Әмирхан.

МИРАЖЛАНУ *ф.* Мираж булып күренү. *Небит-Дагым минем, Аму-Дәрьям, Ни бар бездә — гүзәл шунысы: Миражлайлып яткан тыныч сахра, Каспиемның дымлы сулышы.* Ш. Мөдәррис.

МИРАС *и.* 1. Хуҗа (башлыча ата-ана, якын туган) үлгәч башка берәүнең хосусый милкенә күчә торган мал-мөлкәт, байлык. *Минем атам мирас итеп Алтыннар калдырмаган.* Ә. Ерикәй. *Атадан балага мирас кала килгән бу басуны, сак булыгыз, сата күрмәгез.* Дәрдмәнд. || *сөйл.* Үзеннән элгәре эшләгән, хезмәт иткән кеше тарафыннан файдалану өчен яки бүләк итеп калдырылган нәрсә. *Ал, яшь егет, үткер кылычымны. Миннән сиңа изге мирас ул!..* М. Гафури.

2. Элекке буын культура эшлеклеләреннән, гомумән, үткән чордан калган культура байлыгы һәм көнкүреш әйберләре. *Драматург буларак, Г. Камал татар әдәбияты дөньясы өчен бик бай һәм кыйммәтле мирас калдырган язучы.* М. Гали. [*Егерменче еллар татар әдәбиятында*] *кыен һәм катлаулы мәсьәләләрнең берсе — мираска мөнәсәбәт, мирасны үзләштерү мәсьәләсе иде.* Х. Госман. *Халык җырлары — безнең бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә бәһале мирастыр.* Г. Тукай.

3. *күч. сөйл.* Элекке буын белән хәзерге буын арасындагы охшашлык, уртак сыйфат. *Гомер-гомергә ата-бабадан мирас булып килгән атсызлык, җирсезлек аның тәмам кешелек иркен алды.* Г. Минский.

МИРАСЧЫ *и.* 1. Мирас алучы яки мирас алырга хокукы булган кеше. *Улем җанны ала, мирасчылар малны ала.* Мәкаль.

2. *күч.* Кемнең дә булса эшчәнлеген дәвам иттерүче. [*Ирек:*] *Синең фамилияңдә бу һөнәреңне тагын да алга илтерлек варис булыр кешене — мирасчыны китерәм мин семьябызга.* Н. Исәнбәт.

МИРЗА *и. иск.* 1. Кайбер көнчыгыш халыкларында — өстен катлау вәкиленең титулы; || Шул титулга ия булган кеше. —*Шанлы, дәүләтле, изге нәселле Сәлим мирзаның кызы Хәмдия бер көтүчегә төшәчәк тәкны үзенә кабул итәме?* М. Фәйзи.

2. Кайбер көнчыгыш халыкларында — югары дәрәҗәдәге чиновник яки галимнең почетлы исеме.

МИРЗАЛЫК *и.* Мирза (1 мәгъ.) дәрәҗәсе. [*Фатыйма бикә*] *мәсьәлә кызына килгәч, аның мирзалыгы каядыр югала да, утыз ел гомернең биргән авыллашуы, мөселманлыгы җиңеп, Мәрьямгә Зыядан качуны тиеш таба.* Г. Ибраһимов.

МИРОВОЙ *и. сөйл. к.* мировой судья. [*Мәрәк Фәсхи:*] *Табып китер миңа үз җиремдәге кызыл балчыкны, кәҗә сакалны. Югыйсә, хәзер мировойга барам.* Ф. Хөсни.

Мировой судья — Англия, Франция, Америкада һәм революциягә кадәр Россиядә кешеләр арасындагы төрле бәхәсләрне һәм вак җинаять эшләрен тикшереп хәл итүче судья.

МИ'РРА *и. бот.* 1. Кайбер тропик агачларның кайрысыннан алына торган хуш исле сумала (парфюмериядә һәм медицинада файдаланыла). || *с. мәгъ.* Шул сумаладан алынган. *Мирра мае.*

2. Кайрысында шундый хуш исле сумаласы булган агач.

МИРТ *и. бот.* Хуш исле ак чәчәк ата торган мәңге яшел көньяк агачы яки куак. *Мирт куаклыгы.*

МИСАЛ *и.* 1. Кем өчен дә булса үрнәк, өлге булып хезмәт итә торган эш яки күренеш. *Анда булган тәҗрибә кырларының уңышлары безгә крестьяннар белән беседа алып барган вакытларда көчле мисал булып хезмәт итте ләр.* М. Әмир. || Нәрсәнең дә булса ачык үрнәге, билгесе.— *Бу кечкенә генә китап мисалында мин, язучы буларак, бер хакыйкатьне тагын һәм тагын бер кабат төшендем.* Ф. Хөсни. *Бу шигырь 1918 — 1922 еллар Такташ иҗаты өчен характерлы мисал була ала.* Г. Нигъмәти.

2. Нәрсәне дә булса аңлату, исбат итү, раслау өчен китерелә торган берәр очрак, дәлил. *Майпәрвәз ханым әйткән сүзен исбат итәсе килсә, үз тормышын мисал итеп китерә иде.* Ә. Еники. [*Сурка:*] *Гафу кыйласыз, мин аларга тел тидереп әйтүем түгел, фәкать мисал өчен генә китердем.* Ш. Мөхәммәдев. || Берәр фикергә дәлил итеп китерелгән иллюстратив материал (сүз, җөмлә һ. б). *Ясалма, тәмсез, пешмәгән җырларга --- 2—3 мисал китерә ла.* М. Җәлил.

3. *сөйл.* Чишү өчен бирелә торган математик мәсьәлә, гамәл. *Моның ничек чишелгәнен мисал өстендә күрсәтик.* Алгебра. || Нәрсәне дә булса өйрәнүгә хезмәт итә торган күнегү. *Катя аңа һәр мисалны иренмичә, аерата зур түземлелек белән аңлата һәм русча сөйләгәндә татарчаны онытып торырга куша иде.* Г. Әпсәләмов.

◊ **Мисал өчен** *кер. сүз* — мәсәлән.— *Мисал өчен, без иген чәчеп үстерәбез һәм ел саен, шөкер, хезмәт көнебезгә икмәк булешеп алабыз.* Ә. Еники. **Мисалы булмау (күренмәү)** — охшашы, тиңе булмау, бердәнбер булу, монача күрелмәгән булу. [*Рәис:*] *Без, ипташлар, менә бүгенге кебек мәдрәсә яшьләре тормышының тарихында мисалы булмаган бер вакытка килдек.* Г. Ибраһимов. *Нуретдиннең йөзендә мисалы күренмәгән бер шатлык иде.* Г. Тукай.

МИСАЛЛЫ 1. *с.* Мисалы булган. *Мисаллы аңлатма.*

2. *бәйл. иск. кит.* Кебек, шикелле. *Заман явызлар заманы булса, Адәмнәр бүре мисаллы булырлар.* Мәкаль.

МИСВӘК *и. иск.* Хуш исле махсус сорт агачтан ясалган теш чистарткыч.

МИСЕЗ *с. сөйл.* Аңгыра, миңгерәү (тиргәү, шелтәләү сүзе).— *Белмим, кемгә охшап бу кадәр мисез, акылсыз булгандыр бу.* Г. Камал.

МИСК *и. иск.* Ата кабарганың бизләреннән алына торган хуш исле матдә, мускус.

МИСКИ *и. сөйл. к.* кастрюль. *Сәкегә яңадан җәймә җәелде, чәчәкле зур ак миски белән бу чыгып торган, бөтен өй эчен тәмле, ләззәтле ис белән тутырган аш китереп куелды.* А. Шамов.

МИСЛЕ *бәйл. иск.* Кебек, күк, шикелле, төсле, сыман. *Маңгаена басты карчык ут мөһер, кап-кара булды йөзе мисле күмер.* Ш. Бабич.

◇ **Мисле булмау** — охшашы булмау, тиңе булмау. [*Патшаның*] *дөньяда мисле булмаган бер бик гүзәл кызы бар икән.* М. Җәлил. **Мисле юк** — тиңе юк, охшашы юк. *Карый әфәнде бу Шәехнең укуда да, дөньяда да мисле юк икәнлеген сөйләде.* Ф. Әмирхан.

МИСРАГ *и. кит.* Шигырь юлы. *Вәзен, кафия, мисраг мәсьәләсенә килгәндә, без Бабичта шәрыкъ халыкларының йөргенә якынрак озын мисрагларны күбрәк очратабыз.* Г. Ибраһимов. *Гөлбану җырның актыккы мисрагын озын гына итеп сузып бетергәч, тагын гөрләтеп кул чаптылар.* Ш. Камал.

МИСС *и.* 1. Англия һәм Америкада кияүгә чыкмаган хатын-кызның исеме яки фамилиясе алдыннан әйтелә торган сүз.

2. Патша Россиясендә: буржуаз-дворян семьясындагы гувернантка-тәрбияче инглиз хатын-кызы.

МИССИОНЕР *и.* Башка диндәге халыклар арасында үз динен тарату өчен христиан чиркәве тарафыннан җибәрелгән вәкил. *Победоносцев — патша хөкүмәте вакытында атаклы миссионер һәм Духовный Синод башлыгы.* М. Гали.

МИССИОНЕРЛЫК *и.* Миссионер эшчәнлеге.

МИ'ССИС *и.* Англия һәм Америкада кияүдәге хатынның исеме яки фамилиясе алдыннан әйтелә торган сүз.

МИ'ССИЯ *и.* 1. Йөкләмә, йомыш, тапшырылган эш.— *Бүгенге көндә миндә мөһим миссия — Сабан туен үткәрттерү буенча комиссия.* Ш. Галиев. *Яшь офицер Галим Урманов бу тарихи миссияне (поляклarны, чехословакларны һ. б. фашистлар коллыгыннан азат итү миссиясен) намус белән үтәячәге турында шатланып уйлады.* Г. Әпсәләмов.

2. *юг.* Тарихи һәм җаваплы роль. *Сәнгатьнең бөек миссиясе.*

3. Берәр илдә башында илче яки вәкил булган даими дипломатик вәкиллек һәм шул вәкиллек урнашкан бина.

4. Нинди дә булса илгә махсус эш, берәр максат белән җибәрелгән делегация. *Сәүдә миссиясе. Хәрби миссия.*

МИ'СТЕР *и.* Англия һәм Америкада ир кешенең гадәттә исеме яки фамилиясе алдыннан әйтелә торган хөрмәтләү сүзе; әфәнде. *Бездә, мистер, эшләр әйбәт хәзер, матурланып килә һавалар.* Һ. Такташ.

МИ'СТИК I *и.* Мистицизмга бирелүчән кеше, нинди дә булса дини-мистик теория тарафдары. *Бәлки мине мистик диярләр, әйтсәләр әйтсеннәр.* Г. Газиз.

МИ'СТИК II *с.* Мистикага, мистицизмга бәйләнешле. [*Романда*] *лирик кабатлаулар, сыйфатлауларда дини, мистик сурәтләрнең саклануы һәм шуңа охшаган күренешләр очрый.* Г. Нигъмәти.

МИ'СТИКА *и.* Табигатьтән тыш илаһи, серле көч бар дип ышану; кешенең теге дөнья, ахирәт белән турыдан-туры бәйләнеше бар дип карау. *Мин динле түгел. Мистикага ышанмыйм.* М. Әмир.

МИСТИФИКА'ТОР *и. кит.* Мистификация белән шөгыльләнүче, уйдырма сөйләүче, ялганчы.

МИСТИФИКА'ЦИЯ *и. кит.* Берәр максат белән юри алдау; саташтырып, буташтырып ялган, уйдырма нәрсәләр сөйләү.

МИСТИЦИ'ЗМ *и. кит.* Мистикага нигезләнгән дини-идеалистик караш.

МИСЫР: мисыр бодае *иск.*— кукуруз. **Мисыр күгәрчене** — күгәрченнәрнең яшькелт сары төстәге кечкенә төре. *Өйнең бер почмагында агач читлектә күп еллардан бирле хәзрәтнең күңел җимеше итеп тота торган пар мисыр күгәрченнәре бар иде.* С. Рафиков.

МИСЫРЛЫ *и.* Мисырда туып үскән яки шунда яшәүче кеше. *Борынгы мисырлыларга ук инде планеталар барлыгы мәгълүм булган.* Астрономия.

МИ'ТИНГ *и.* Политик яки көн үзәгендә торган берәр мәсьәлә буенча зур җыелыш. *Ул, эшчеләр митингысында байларга каршы сөйләгән өчен, полиция тарафыннан кулга алынып, ике ел ярым ябып яткырыла.* М. Гали.— *Митингка туры килсәң, „Чулпан“ халкы исеменнән бер-ике яхшы сүз әйт.* Г. Бәширов.

МИТКАЛЬ *и.* Полотно сыман юка мамык тукыма. || *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән. *Миткаль күлмәк.*

МИТРОПОЛИТ *и.* Православие һәм католик чиркәүләрдә иң югары епископ дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәгә ия булган кеше.

МИТРОПО'ЛИЯ *и.* Митрополит идарәсенә кергән чиркәү-административ округ һәм шул округның баш шәһәре. *Киев митрополиясе.*

МИФ *и.* 1. Аллалар, легендар батырлар һәм дөньяның, җирдәге тормышның килеп чыгуы турында борынгы халык әкиятләре. *Миф буенча, елан йөзгә кадәр яшәсә, аждаһа була.* М. Җәлил.

2. *күч.* Фантастик әйбер, уйдырма, хыялый нәрсә; чынбарлыкка туры килми торган караш. *Совет Армиясе фашизмның җиңелмәслеге турындагы мифның көлен күккә очырды.* Соц. Тат.

МИ'ФИК *с.* 1. Мифтан алынган. *Мифик образ. Мифик сюжет.*

2. *күч.* Әкияткә, мифка охшаган. || Уйдырма, уйлап чыгарылган. *Алар [им-том, ырымнар белән] үзләренә дошман булган мифик көчләрне, үлекләрне юаталар, яки берсүзсез җиңәләр, куалар һәм гомумән бәлаләрдән котылырга тырышалар.* К. Насыйри.

МИФО'ЛОГ *и.* Мифология (2 мәгъ.) белгече.

МИФОЛО'ГИК *с.* Мифологиягә бәйләнешле, мифларга нигезләнгән. *Мифологик хикәя.* □ *Иске хорафатларда куркынычлы итеп сөйләнеп йөртелгән мифологик образлар: дию пәрие, су анасы һ. б. К. Насыйри җыйган вариантларда кешеләр тарафыннан җиңеләләр.* М. Гайнуллин. *Татар фольклорында усал, кытыклап үтерә торган рәхимсез „табигать иркәсе“ — мифологик шүрәледән гыйбарәт.* Г. Нигъмәти.

МИФОЛО'ГИЯ *и.* 1. Мифлар (1 мәгъ.) җыелмасы, мифлар системасы. *Грек мифологиясе.*

2. Мифларны (1 мәгъ.) өйрәнә торган фән. *Насыйриның русчага тәрҗемә ителгән әсәрләре башлыча татарның этнографиясе, мифологиясе һәм халык әдәбияты турында.* Г. Ибраһимов.

МИХНӘТ *и.* Көн күрү, яшәү, хәтта тукланы өчен кирәкле нәрсәләргә булган мохтаҗлыклар аркасында күрелгән газаплар, авырлыклар, кыенлыклар; хәерчелек, фәкыйрьлек. *Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап, михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән.* Г. Кутуй. *Гомуми бәла, гомуми гаҗизлек һәм михнәтләр әлбидәне дә үз эченә бөтереп алды.* Ш. Маннур. || Гомумән, авырлык, кыенлык, газап, мәшәкать. *Байлар алдына кат-кат*

барып, йөз суы түгеп, бик күп михнәтләр белән алган егерме-утыз сумлык сәдака акчасына --- рәтле бернәрсә дә эшләргә мөмкин булачак түгел иде. М. Гали.— *Авыр... авыр, туган, көнебез, Ардым инде: михнәт бетерде.* Ф. Бурнаш. | *с. мәгъ. Авыр михнәт еллары.*

◊ **Михнәт күрү (чигү)** — авырлык, газап, кыенлыклар кичерү, җәфа чигү. *Күрмә михнәт, яшә рәхәт, Дустым, сиңа теләгем.* Жыр.

МИХНӘТЛЕ *с.* Авыр, кыен, газаплы, җәфалы. *Солдат кайтыр туган җирләренә, Кичеп ерак-ерак юлларны; Онытмаслык булып гомер буе, Бу михнәтле авыр елларны.* Ш. Маннур. *Җәмиләнең эчендә булган бала буйлә михнәтле дөньяга, хәсрәтле өйгә, ярлы тормышка туасы килмәгән кебек...* М. Гафури.

МИХНӘТЛӘНҮ *ф.* Интегү, җәфалану; газап чигү, михнәт күрү. [*Бибкәй Мавиягә:*] *Шундый яшьлегең, сылу буең, ай кебек матур йөзең була торып, номер идәннәре юып, керләр уып михнәтләнгәнче, мин әйткәнчә генә [эшләсәң]!* М. Фәйзи.

МИХНӘТТӘШ *с. сир.* Кем белән булса да бердәй михнәт күрүче. *Муса аны һаман да бары тик һәйбәт, акыллы кыз итеп, якташ һәм михнәттәш дус итеп ярата иде.* Ш. Маннур.

МИХРАБ *и. дини.* Мәчеттә мулла намаз укыр өчен билгеләнгән махсус урын, түр. *Мөнбәр белән михраб арасында кинәт яктырып китеп, дәрвиш белән егетнең бераз вакыт күзләре камашып тора.* Ш. Камал. *Сабит хәзрәт аклар белән китте; мәхәллә башлыксыз, михраб имамсыз калды.* Сов. әд.

МИЧ *и.* **1.** Бинаны җылыту, азык пешерү өчен кирпеч яки тимердән эшләнгән җайланма. *Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач.* Табышмак. *Тимер мич дөрләп яна башлады.* Г. Әпсәләмов. *Дни мич тирәсендә коймак пешереп йөри иде.* М. Гафури.

2. Технологик процесслар вакытында материалларны кыздырып эшкәртү өчен хезмәт итә торган корылма. *Кирпеч яндыру миче.* □ *Бер ел буе газда эшләгәндә, Җитез булганмыдыр эшендә, Хәзергесе көндә сары Хисмәт Чуен эретә домна мичендә.* Ш. Маннур.

Мич алды — 1) мичнең авызы урнашкан ягы; 2) идәннең мич авызы турындагы өлеше; 3) гомумән, өйнең кухня итеп файдаланыла торган өлеше. **Мич арты** — 1) мич авызына каршы як; мич белән стена арасы; 2) *күч.* дөньядан, тормыштан аерылып яшәү турында.— *Ни генә әйтмәсеннәр, мин, борынгы киленнәр кебек, мич артына гына сыя алмыйм.* Г. Бәширов. **Мич ашы** — өчпочмак, бәлеш һ. б. ш. кебек мичтә пешерелгән ашамлыклар, таба ашлары. [*Хәнифә:*] *Чәй эчәргә ник кайтмыйсың, балам? Дәрәк мич ашы да пешергән идем.* Р. Ишморат. **Мич башы** — мич өстендә әйберләр киптерү яки йоклау өчен эшләнгән махсус мәйданчык. *Мич башыннан егылып төшүнең дә рәте бар.* Әйтем. **Мич казнасы** — мичнең нигезе. [*Кабанов:*] *Ул мич казнасында нәрсә булыр дип уйлыйсың?* Т. Гыйззәт. **Мич куышы** — мичнең тышкы стенасында оек, бияләй, итек һ. б. ш. кую, киптерү өчен махсус калдырылган куыш сыман урын. *Хәлим, кайтырга кирәк инде, дип, мич куышыннан аякчуларын алып чолгарга тотынганда, капка әкрен генә, бер дә шыгырдамыйча гына ачылып китте.* Г. Гобәй. **Мич көймәсе** — мич эченең гөмбәзләнеп торган түбәсе. *Шәрифулла инде мич көймәсен тезә иде, шул вакыт Зифа карчык аны табын янына, көндезге ашка чакырды, әмма кире җавап алды.* А. Шамов.

◊ **Мич башына менү** — эштән, хезмәттән читләшү. *Менмәмен мин, ходай кушса, мич башына.* Г. Тукай. **Мич башында (таракан санап) яту** — эшләми яту, ялкауланып тик яту. *Андый салкын көндә акыллы кеше мич башында гына ята, ә без тинтәкләр базарда йөрибез.* И. Гази. **Мич томалау** — утын янып беткәч, моржасын ябу.— *Мичне бик кызу томалагансың, ахры, исерерсең бит монда.* М. Гали. **Мич үрләтү** — мичкә ягып җибәрү. **Мич уздыру** — 1) мичне томалап кую; 2) мичне ягып, пешерәсе нәрсәләрне пешереп, мичкә бәйле эшләрне бетерү. *Ул табын хәзерләште, мичне уздырып, тәрәзәдәге такталарны алды.* К. Нәҗми.

МИЧКӘ *и.* **1.** Ике баштан да яссы төпле, цилиндр формасындагы яки кабарынкы корсаклы, тимердән яки тар гына такталардан эшләнгән зур савыт. *Бензин мичкәсе.* □ *Бервакытны, бодай туфракны каплап җиткермәс борын, Яурышкан буена кырык чиләк керешле зур мичкә җигеп килделәр.* Г. Бәширов.

2. *сөйл.* Кырык чиләккә туры килә торган сыеклык үлчәү берәмлеге.

◊ **Мичкә кебек** — бик зур, юан. *Мичкә кебек корсакларына Гофман сырасын тутыралар.* Ш. Мөхәммәдев. **Мичкә корсак** — 1) зур, юан корсак турында. *Корсагым иде мичкә, күтәреп йөрдем көчкә.* Г. Камал; 2) юан корсаклы кеше яки гомумән байлар турында. [*Шәрәфи карт:*] *Кайчагында бернәрсәгә дә карамыйча, шушы мичкә корсак сволочьларга тире кыра торган чалгы белән ташланырдай итәсең.* Ш. Камал; 3) эчкечә, аракы күп эчә торган кеше.

МИЧКӘЛЕ *с.* Мичкәгә салынган. *Мичкәле сыра.*

МИЧКӘЛӘП *рәв.* Мичкә белән.—*Йөз адым елгадан суны мичкәләп ташыйбыз.* Ә. Еники.— *Башкорттан мичкәләп кымыз алдырам.* Г. Ибраһимов.

МИЧКӘЧЕ *и.* Мичкә ясаучы. *Бездә мичкәче Сабир бабай бар иде.* Каз. утл.

МИЧКӘЧЕЛЕК *и.* Мичкә ясау һөнәре.— *Күрше рус авылында мичкәчелек белән дан тотканнар.* Соц. Тат.

МИ'ЧМАН *и.* **1.** СССР Хәрби диңгез көчләренең старшиналар составындагы өлкән дәрәҗә һәм шул дәрәҗәне алган кеше.

2. Патша Россиясе флотында — беренче офицер дәрәҗәсе; шул дәрәҗәдә булган офицер.

МИ'ЧМАНЛЫК *и.* Мичман булу вазифасы, дәрәҗәсе.

МИЧУ'РИНЧЫ *и.* Биологияне һәм авыл хуҗалыгын үстерүдә совет галиме И. В. Мичурин нигезләгән материалистик тәгълимат тарафдары. [*Илсөярнең*] *абыйсы да агроном-мичуринчы.* Н. Исәнбәт.

МИЧЧЕ *и.* Мич чыгаручы, мич салучы. [*Чатан Шәрифулла*] *авылда бердәнбер мичче.* А. Шамов. *Авылның атаклы балта осталары Тимбиккә йорт бурады, миччеләр мич чыгарды.* Г. Ахунов. || Мич янында эшләүче, мичкә ягып торучы; *русчасы:* истопник. [*Хәким ага*] *патша заманында 13 яшьтән Бондюг заводының күкерт кислотасы цехында мичче ярдәмчесе булып эшләве турында сөйләрме?* Соц. Тат.

МИЧЧЕЛЕК *и.* Мичче булу, мич чыгару һөнәре, эше. *Миччелек белән шөгыльләнү.*

МИЧӘҮ I *и.* Гадәттә атны янга җиккәндә тәртә хезмәтен үти торган аркан яки каеш перәшкә. *Ике учакка бер кисәү, ике атка бер мичәү.* Мәкаль.

МИЧӘҮ II *ф.* **1.** Атны янга җигү, мичәүләү.—*Минем рысакны төпкә, ике яшь айгырны перәшкәгә мичәп, резин көпчәкне җиксеннәр.* Т. Гыйззәт.

2. *и. мәгъ. күч.* Ярдәмче. *Өй эчендә ничәүсең, бер-береңә мичәүсең.* Мәкаль.

Мичәү аты — 1) мичәүгә, янга җигелгән ат; 2) *күч.* ярдәмче көч. **Мичәүгә (мичәп) җигү** — 1) янга җигү.

[*Чуваш*] *иң яхшы күк юргасын төпкә, алмачуар чабышкасын мичәүгә җигеп, кыңгырау да таккан иде.* Г. Ибраһимов. *Чанага мичәп җиккән кечерәк кенә ике туры ат ишек алды уртасына килеп туктаганнар иде.* М. Гали; 2) *күч.* эшкә ярдәмче көч итеп файдалану. [*Тимери*] *Нәфисәнең картлар янында салам кыстыруын ишеткәч: „Кара безнең киленне, картларны ничек итеп мичәүгә җигеп куйды!“ — дип, мыек астыннан көлеп утырды.* Г. Бәширов.

◇ **Мичәүдә бару** — эштә, хезмәттә ярдәмче көч булу. **Мичәүдә баручы** — ярдәмче кеше; ярдәмче, өстәмә көч. [*Газзән:*] *План тулыр. Без монда төп көч түгел — мичәүдә баручылар гына.* Г. Әпсәләмов.

МИЧӘҮЛЕ *с.* Мичәүләп җигелгән, мичәү аты җигелгән (мәсәлән, арба, сабан һ. б.)

МИЧӘҮЛӘҮ *ф.* Мичәп җигү, мичәүгә, янга җигү (атны).

МИШЕНЬ *и.* 1. *махс.* Ату күнегүләрен ясау өчен куелган яки билгеләнгән төбәү ноктасы.— *Әллә нигә күз начарланып киттте, мишеньгә дөрес бәрми.* Г. Гобәй. | *с. мәгъ. Алар берәр кеше аткан саен, дер килеп кубып, мишень тактасы янына йөгерештеләр.* И. Гази. || Ату объекты булган предмет. [*Арттагы арбалардан:*] *Юл тигез чакта куалый төш! Эх, син, мишеньгә әйләндереп бетердең ич күк айгырны, — дип сукранырга тотындылар.* К. Нәҗми.

2. *күч. сөйл.* Мәсхәрәләү, тәнкыйтьләү, җәфалау яки эзәрлекләү объекты (кеше яки предмет).

МИШӘР *и.* Татар теленең көнбатыш диалектында сөйләшә торган этник төркем вәкиле. *Икенче көнне шул Мөхәммәтша мишәрнең туенда булдым.* Ш. Мөхәммәдев. *Бертуганнар дисәң, мин Тамбовтан, ә син Казан артыннан, Мин — бер мишәр улы кыргый үскән, ә син — Күрше чуваш халкыннан.* Һ. Такташ.

МИШӘРЛЕК *и.* Мишәр булу, көнбатыш диалект вәкиле булу.

МИШӘ'РЧӘ *рәв.* Мишәрләр сөйләшенчә. *Аның теле бераз башкортчарак, ә минем тел бераз мишәрчә.* Х. Туфан.

МИШӘ'РЧӘЛӘП *рәв.* Мишәр диалекты, акценты белән, мишәр диалекты үзенчәлекләрен чагылдырып. *Мишәрчәләп җырлау.*

МИЯУ *аваз.ияр.* Мәче кычкырган тавышны белдерә. *Мияу-мияу, пескәем, Хыянәтче икәнсең. Саклый торган маеңны Үзең ашап киткәнсең.* М. Җәлил.

МИЯУБИКӘ *и.* Песи, мәче (балалар телендә).

МИЯУЛАУ *ф.* „Мияу-мияу“ дигән тавыш чыгару. *Мәче мичкә янында мыраулап, мияулап, пешкән үрдәкне ашап ята.* Г. Тукай.

МИҢ *и.* Тәндә тумыштан була торган тап яки төерчек. *Бу юлы инде* [*кызның*] *бит очындагы кечкенә миңенә чаклы күреп калдым.* Ф. Хөсни. *Биткәенең иң очында миң яраткан, Саклар өчен зифа буен яман күздән.* Дәрдмәнд.

МИҢГЕРӘТКЕЧ I *и. бот.* Паслёнчалар семьялыгына керә торган сары чәчәкле агулы үсемлек; *русчасы:* желтый паслён. *Миңгерәткеч күбрәк көньяктарак үсә; аларның яфракларындагы һәм орлыкларындагы агулы матдәләр кешене үтерергә дә мөмкин.* Ботаника.

МИҢГЕРӘТКЕЧ II *с.* Аңгы-миңге итә торган, миңгерәүләтә торган. *Миңгерәткеч газ.*

МИҢГЕРӘТУ *ф. к.* миңгерәүләтү. *Йокы миңгерәтә.* Г. Кутуй.

МИҢГЕРӘЮ *ф. диал. к.* миңгерәүләнү. *Сыер савучылар, һушларына килә алмагандай, беркавым миңгерәеп йөрделәр.* М. Хәсәнов.

МИҢГЕРӘҮ I *ф. к.* миңгерәүләнү. *Миңгерәгән ул, уе тарала, Урам буйлап бара да бара.* Ф. Кәрим. *Кинәт башы миңгерәп китте.* Ә. Айдар.

МИҢГЕРӘҮ II *и. сөйл. кимс.* Аңгыра кеше, аңсыз, аңгы-миңге кеше.— *Теге миңгерәүләр азык, эш нормасы дип сөйләгән булалар.* Т. Гыйззәт. [*Закир*] *Миңгерәүләрне алдау да, изү дә ансат.* Г. Иделле.

◇ **Миңгерәү баш** — аңсыз, аңгыра, аңгы-миңге мәгънәсендә әйтелә. [*Бикмулла:*] *Ә-ә... Сез әнә нәрсә турында сорыйсыз икән! Вәт миңгерәү баш, сизми торам.* Ә. Еники.

МИҢГЕРӘҮЛЕК *и.* Миңгерәү (II) булу хәле. *Күңелдәге әллә нинди бер ургып тору, авыздагы тәмсезлек, баштагы миңгерәүлек аңар кичә үзенең исерек булганлыгын хәтерләтте.* Ф. Әмирхан.

МИҢГЕРӘҮЛӘНҮ *ф.* Аңгыралану, аңгы-миңгеләнү, аңгы-миңге булу. *Кыз, үзен тагы да куерак соры томан эчендә калгандай тоеп, тәмам миңгерәүләнеп йөрде.* Каз. утл. *Хәдичә тути Газиз хәсрәте, тормыш мәшәкате белән миңгерәүләнеп йөргән арада, аның төпчек улы егет булып җитә язган лабаса!* Г. Бәширов.

МИҢГЕРӘҮЛӘТҮ *ф.* Аңгыралату, аңгы-миңге итү. *Җепшек кар, кислород кытлыгы — болар барысы да көннәр, айлар үтү белән кешене шулхәтле изә, миңгерәүләтә.* Г. Әпсәләмов.

МИҢКҮ *ф. диал.* Хәлсезләнү, әлсерәү.

Миңкеп яту — хәлсезләнеп, әлсерәп яту. *Көзге яңгыр астында минут саен үлем көтеп миңкеп ятуны „дөнья“ дип атап булса, әйе, дөньяда әле Сәфәргали дигән кеше дә бар иде.* Ф. Хөсни.

МИҢЛЕ *с.* Миңе булган. *Авызы миңле — ашлы, күзе миңле — яшьле.* Мәкаль. *Бикә белән Морза, ананың ай-вәена карамыйча, теге миңле кызны үзләре белән алып киттеләр.* Г. Галиев.

МИҢРӘТКЕЧ *с. сөйл.* Хәлсезләндереп, әлсерәтеп аңгы-миңге хәлгә китерә торган. *Миңрәткеч исереклектән айныган шикелле кинәт аңышып, күзләремне зуррак ачып җибәрдем.* Сов. әд.

МИҢРӘҮ *ф. к.* миңгерәү I.

Миңрәп калу — миңгерәүләнеп, куркып, аптырап калу. *Егет, сөт чүлмәген җиргә төшереп ваткан кыз бала төсле, миңрәп калды.* К. Тинчурин.

МИҺАҺАЙ *аваз.ияр.* Ат кешнәгән тавышны белдерә.

Миһаһай итү — *к.* миһаһайлау.

МИҺАҺАЙЛАУ *ф.* Миһаһай авазлары чыгару. *Әрәм мәгъ. Айгыр кинәт миһаһайлап кешнәп җибәрде.* М. Хәсәнов.

МИҺЕРБАН *и.* Рәхим-шәфкать, мәрхәмәт, кешелеклелек, яхшы күңел, йомшак күңел. [*Комиссия члененарыннан*] *билбаулының чыраенда миһербанның шәүләсе дә күренми иде.* Г. Бәширов.

◇ **Миһербан иясе** — рәхимле, шәфкатьле, яхшы күңелле кеше турында. **Миһербаны килү** — күңеле йомшару, берәр кешегә карата шәфкатьләләнү.

МИҺЕРБАНЛЫ *с.* 1. Рәхимле, шәфкатьле, мәрхәмәтле, кешелекле, яхшы күңелле, йомшак күңелле. — *Мәрһүм Миңһаҗ абзыйны әйтәм әле, бик тә юмарт, бик тә миһербанлы кеше иде.* А. Расих.— *Ходаның рәхмәте белән эшне җайласак, сездән бер генә бөртек җылы сүз, миһербанлы вәгъдә алсам, хаҗи аның ишедән генә тукталып тормас, алла боерса.* Ш. Камал.

2. *күч.* Рәхимле, шәфкатьле; җайлы, җиңел, мәшәкатьсез, уңай. *Еллар миңа миһербанлы булды.* Каз. утл.

МИҺЕРБАНЛЫК *и.* Миһербанлы кешегә хас сыйфатлар. *Саф күңел кешеләрдән яхшылык, миһербанлык, шәфкатьлек көтә ул.* М. Хәсәнов.

Миһербанлык итү (күрсәтү) — шәфкать, мәрхәмәт күрсәтү, яхшылык итү.— *Рәхмәт, кызым, миһербанлык күрсәтүең өчен.* С. Рафиков. **(Күңеленә) миһербанлык салу** — яхшыру, акылга килү. [*Хисам:*] *Кем белә әле, бәлки, аллаһы тәгалә баланың күңеленә миһербанлыклар салыр, бәлки, рәтләнер әле үзлегеннән дә.* А. Расих.

МИҺЕРБАНЛЫЛЫК *и.* Миһербанлы булу сыйфаты.

МНЕМО'НИК *с. кит.* Мнемоникага бәйле. *Мнемоник алымнар.*

МНЕМО'НИКА *и. кит.* Мөмкин кадәр күбрәк фактларны, мәгълүматларны истә калдырырга ярдәм итә торган алымнар һәм кагыйдәләр җыелмасы. *Мнемониканың яңа ысуллары.*

МОБИЛИЗАЦИОН *с.* Мобилизациягә караган, мобилизация белән бәйле. *Мобилизацион план. Мобилизацион хәзерлек.*

МОБИЛИЗА'ЦИЯ *и.* 1. Сугыш башлану уңае белән запастагы хәрби хезмәткә яраклы кешеләрне солдат хезмәтенә алу. *Бөтен илдә армиягә мобилизация бара иде.* И. Гази. || *күч.* Хезмәт ияләрен, барлык көчне нинди дә булса ашыгыч гомум бурычны үтәү өчен туплау, оештыру эше. — *Безнең партия, мингә кебек крестьян арасыннан килеп чыккан членнарга мобилизация үткәреп, авылларга чыгарды.* Т. Гыйззәт.

2. Тыныч вакыттагы барлык кораллы көчләрне сугышчан хәлгә күчерү. || Халык хуҗалыгының барлык өлкәләрен хәрби хәлгә күчерү.

МОБИЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Мобилизация үткәрелү.

2. Мобилизация буенча җибәрелү, мобилизациягә тартылу. [*Комсомоллар*] *үзләрен һәрвакытта, һәркайда коммунистик төзелешнең бөек эшенә мобилизацияләнгән дип исәплиләр.* М. Хөсәен.

МОБИЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Мобилизация үткәрү. *Армияне мобилизацияләү.*

2. Берәр мероприятие үткәрү өчен оештыру. *Бөтен кешене, ат һәм машина көчләрен чисталык өчен көрәшкә мобилизацияләргә кирәк.* М. Әмир. *Бөтен коллективны мобилизацияли алсак кына эшне үтәп чыгарбыз.* Г. Әпсәләмов.

МОГИКАН *и.* 1. Төньяк Америкада яшәгән һәм үлеп беткән индеецлар кабиләсенең атамасы һәм шул кабиләнең аерым бер кешесе.

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса соңгы яки бик өлкән вәкилләреннән берсе.— *Ә ул безнең төнге сторож, кызык карт бик. Могиканнарның соңгысы.* Э. Фәйзи.

МОГТӘБӘР *с. кит.* Хөрмәтле; абруйлы, күренекле. [*Фатыйма*] *үзе авылның мулла-мазине белән берничә могтәбәр аксакалыннан башка адәмнән качмый.* Г. Ибраһимов. *Гали — бер могтәбәр кеше улы.* Ф. Әмирхан.

МОГҖИЗА *и.* 1. Дини һәм мифик күзаллаулар буенча: табигать законнарына бәйле булмаган, табигатьтән өстен көч һәм шул көч ярдәмендә барлыкка килгән хәл, күренеш. *Хәзер бер-бер могҗиза булып, әти кайтып керсә иде!* Каз. утл. *Укыталар иде ул вакытта Төрле пәйгамбәрләр кыйссасын һәм аларның төрле могҗизасын.* М. Гафури.

2. Гаҗәпләнерлек, искитәрлек нәрсә, көтмәгәндә, уйламаганда күз алдына килеп баскан, гадәти булмаган нәрсә, күренеш.— *Колхоз булгач, бу кеше дигәнең әллә нинди могҗизалар эшли башлады.* Г. Гобәй. [*Зиннәтнең*] *могҗизалар тудыра торган сул кулы канлы ит кисәгенә әйләнгән иде.* Г. Бәширов. || Гаҗәпләнү, соклану хисе тудыра торган берәр кеше яки предмет турында. *Җирнең бер читеннән бер читенә Тавыш килү — бу бер могҗизамы?* М. Гафури. *Алга бара кораб, бозлар арасында, Могҗизалар менә кайда ул!* Ф. Кәрим.

МОГҖИЗАЛЫ *с.* Гаҗәп, искитәрлек, шаккатарлык; әкияттәгедәй. *Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсу-ак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде.* Ф. Әмирхан. || Могҗизалар булдыра торган.— *Кара әле, могҗизалы карт бабай, безнең авылыбызда әхмәт дигән бер батыр бар иде.* Д. Аппакова. || Серле. — *Нинди могҗизалы очрашу булды бу!* М. Фәйзи.

МО'ДА *и.* 1. Билгеле бер җәмгыятьтә билгеле бер вакыт дәвамында киемгә, туалетка, тормыш кирәк-яракларына карата теге яки бу гадәтләр, зәвыклар өстенлеге. *Иске мода.* □ *Карыйм, үзебезнең кунак булмәсе: артык зиннәтләнгән; иң соңгы мода белән җыештырылып, аңкып торырлык мәртәбәдә хуш ис белән бөркетелгән.* Г. Ибраһимов.

2. *күпл.* Заман һәм сезон таләпләренә, зәвыкларына җавап бирерлек, туры килерлек кием үрнәкләре. *Модалар журналы. Сезон модалары.*

3. *сөйл.* Гадәт. *Мода булды сары алтынга сатылу. Болар бар да Столыпин ысулы имди.* Ш. Мөхәммәдев.

Мода(лар) ателье — төрле фасондагы индивидуаль киемнәр тегү мастерское.

◇ **Модада (булу)** — 1) модалы итеп исәпләнү; 2) гадәти булу, гадәткә керү; 3) киң таралу; игътибар үзәгендә булу яки кызыксыну уяту. *Бу вакытта зәңгәр күзләр турындагы җыр бик модада иде, гүя аны Мөслимә турында чыгарганнар.* Г. Әпсәләмов. **Модадан чыгу (төшү)** — төсе, формасы, фасоны һ. б. ш. буенча искерү, модалы булмау. *Акча биреп алучы кеше дә модадан чыккан, кибеттә аунаган үтмәс товарны аласы килмидер.* Ш. Мөхәммәдев.

МО'ДАДАГЫ *с.* 1. Модадан чыкмаган, мода таләпләренә туры килә торган; модалы.

2. *сөйл.* Гадәти, гадәткә кергән, (нинди дә булса бер төркем халык арасында) таралган. *Көтәргә күпләп мал алып, аны бөтенләй түләми калу яки 5—10 процентын гына түләп котылу бик модадагы әйбер иде.* М. Гали.

МО'ДАЛЫ *с.* Мода таләпләренә җавап бирә торган, зәвык белән эшләнгән, зәвыклы. *Модалы күлмәк.* □ *Зөбәржәт өстенә аксыл-сары костюм-күлмәк, башына шуңа иш төстәге киң кырыйлы модалы эшләпә кигән иде.* А. Расих.

МОДАЛЬ *с. лингв.* Модальлек белдерә торган. *Модаль сүзләр.*

МОДАЛЬЛЕК *и. лингв.* Сөйләм әйтәлегенең чынбарлыкка карата мөнәсәбәтен билгели һәм аны кереш сүзләр, интонация, фигыль төркемчәләре, хәбәрлек сүзләр һ. б. аша белдерә торган грамматик категория.

МОДЕЛИЗМ *и. тех.* Машина (самолет, судно һ. б. ш.) механизмнарын һәм корылмаларын конструкцияләү, төзү һәм сынап карау эшләре.

МОДЕЛЬ *и.* 1. Нинди дә булса әйбернең үрнәк өчен эшләнгән нөсхәсе. *Хатын-кыз күлмәкләре модельләренең күргәзмәсе.*

2. *тех.* Берәр нәрсәнең кечерәйтеп ясалган үрнәге яки схемасы. [*Әпсәләмовның*] *планёр моделе бик әйбәт иде.* Г. Кутуй.

3. Конструкциянең маркасы, тибы. *Автомобильнең яңа моделе.*

4. *тех.* Эретеп кою эшендә кулланыла торган калып, өлге.

МОДЕЛЬЕР *и.* Модельләр (1 мәгъ.) хәзерләү белгече. *Безнең модельерлар яңа форма тәкъдим иттеләр.* Соц. Тат.

МОДЕЛЬЛЕ *с.* Югары сыйфатлы, иң соңгы мода буенча эшләнгән. *Модельле туфлилэр.*

МОДЕЛЬЧЕ *и. махс.* Модель (2 мәгъ.) ясаучы, калыпчы, калып хәзерләүче эшче.

МОДЕРН *и. махс.* XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башындагы архитектура һәм практик сәнгать өлкәсендә үзенең артык чуарлыгы, ясалма һәм формалистик булуы белән аерылып торган төшенкелек чоры художество стиленең атамасы. *Модерн ысулындагы гостиница.*

МОДЕРНИЗА'ЦИЯ *и.* 1. Заман таләпләренә һәм зәвыкларына җавап бирерлек итеп нәрсәне дә булса үзгәртү, яңарту эше.

2. Иске яки борынгы нәрсәләргә үзләренә хас булмаган үзгәрешләр, яңалыклар кертү эше.

МОДЕРНИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Модернизация ясау, үткәрү, кертү. [*Машиналарны арттыру проблемасын*] *күбрәк иске станокларны модернизацияләү исәбенә хәл итәргә туры килер.* Г. Әпсәләмов.

МОДЕРНИЗМ *и. кит.* Империализм чорындагы буржуаз әдәбиятта һәм сәнгатьтә реализмга дошман булган реакцион агымнарның гомуми атамасы. *Алар кешене чынбарлыктан, көрәштән аера, ераклаштыра торган модернизм, декадентлыкны яклыйлар.* Г. Халит.

МОДЕРНИСТ *и.* Модернизм тарафдары. *Әдәбиятта һәм сәнгатьтә марксистик-ленинчыл принциплар буржуаз идеологларның, модернистларның туктаусыз һөҗүмнәренә очрый.* Соц. Тат.

МОДИ'СТКА *и. иск.* Хатын-кыз эшләпәләре мастеры. || Хатын-кыз күлмәкләре һәм туалет әйберләре тегүче. *Бөтен дөньяга мәшһүр модалар уйлап табучы модисткалар Парижда яшиләр.* Г. Гали.

МОДИФИКА'ТОР *и.* 1. *техн.* Машинаның хәрәкәтен һәм, гомумән, эшне модификацияләү (үзгәртү) өчен җайланма.

2. *хим.* Эретелгән чуенның механик сыйфатын, хосусиятен арттыру өчен салына торган (өстәмә) масса.

МОДИФИКА'ТОРЧЫ *и.* Модификаторлар цехында эшләүче. *Модификаторчыларның эше, күп эзләнүләр белән тулы булган киеренке хезмәте моннан берничә ай элек үк башланган иде инде.* Соц. Тат.

МОДИФИКА'ЦИЯ *и. кит.* 1. Предмет яки күренешнең асылын бозмыйча башка төргә күчерү, үзгәртү.

2. Шундый күчеш, үзгәрешкә дучар булган предмет яки күренеш.

МОДИФИКА'ЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Нәрсәгә дә булса модификация ясау.

МО'ДНИЦА *и. сөйл.* Модадан калышмыйча, модача, яңа мода белән киенә торган хатын-кыз, модага иярүче хатын-кыз. [*Геннадий Мәрфуга турында:*] *Модница дип сөйләгән идең, шул кызмы?* Г. Ахунов.

МОДУЛЬ *и.* 1. *физ., тех.* Кайбер коэффициентлар исеме. *Эластиклык модуле.*

2. *мат.* Нинди дә булса бер система логарифмын табу өчен башка система логарифмын тапкырларга кирәк булган сан.

МОДУЛЯ'ТОР *и. тех.* Радиотапшыргычларда, киноаппаратларда тирбәнешләрнең модуляция процессын башкара торган җайланма.

МОДУЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. *муз.* Бер тоннан икенче тонга күчү; тавыш югарылыгы үзгәрү.

2. *физ.* Башка түбәнрәк ешлыклы тирбәнешләргә мөнәсәбәттә югары ешлыклы тирбәнешләрнең характеры үзгәрү.

МОЗА'ИК *с.* Мозаика рәвешендәге, мозаикага охшаган. || Мозаика белән бизәлгән.

МОЗА'ИКА *и.* 1. *сәнг.* Юеш цемент, штукатура яки мастика өстенә төрле төстәге пыяла, вак таш, эмаль, мрамордан һ. б. ш. оештырып ясалган художестволы бизәк. *Художниклар сарайларның стеналарын мозаикалар белән бизәгәннәр.* Урта гас. тар. *Күз алдына стеналары мозаика белән бизәлгән балалар павильоннары килеп баса.* Каз. утл. || *җый.* Шундый бизәк өчен файдаланыла торган пыяла, мрамор, төсле таш кисәкләре.

2. Шундый бизәкләрне эшләү сәнгате.

3. *күч.* Күп төрле элементлардан торган катлаулы, чуар катнашма.

МОЗА'ИКАЧЫ *и.* Мозаика остасы.

МОКАСИН *и.* Төньяк Америка индеецларының йомшак күннән эшләнгән оекка охшаш аяк киеме.

МО'ККО *и.* Кофеның кыйммәтле сорты.

МОКЫТ *с. диал.* Аңсыз, аңгыра, мәнсез. *Сез тагын [Петяны] томана, мокыт нәрсә икән дип уйлый күрмәгез. Һич алай түгел.* Ә. Еники.— [*Нәгыйм*] *бик мокыт нәрсә иде ләбаса. Ничек итеп теге юлбасарлар үзләренең шайкаларына керткәннәр?* Ш. Камал.

МОКЫТЛАНУ *ф. диал.* Аңгыралану, аңсызлану, мәнсезләну. || Мокыт сыман кылану.

МОКЫТЛЫК *и. диал.* Мокыт булу, мокыт кешегә хас сыйфатлар. *Әгәр ул тәрәзәгә килмәсә, бу бик зур игътибарсызлыктан, мокытлыктан санала.* С. Сүнчәләй.

МОЛ *и.* Портларны, судноларны дулкыннан саклау өчен хезмәт итә торган корылма, биек дамба. *Дулкыннар, күкрәкләрен алга терәп, молга каршы килеп бәрелделәр һәм үлек булып кире кайттылар.* Г. Коләхметов.

МОЛДАВАН *и.* Молдавия ССРда яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Минем белән бергә төрекмәннәр, молдаваннар утырып баралар.* С. Хәким.

МОЛЕ'КУЛА *и.* Матдәнең төп химик үзенчәлекләренә ия булган иң кечкенә кисәге. *Молекулалар тагын да ваграк кисәкчекләрдән — атомнардан тора.* Физика.

МОЛЕКУЛЯР *с.* Молекулага мөнәсәбәтле. *Молекуляр төзелеш. Молекуляр авырлык.* || Молекулаларны өйрәнүгә бәйле. *Молекуляр физика. Молекуляр теория. Молекуляр гипотеза.*

МОЛЕСКИН *и. махс.* Спорт, эш киемнәре тегү өчен файдаланыла торган калын һәм чыдам мамык тукыма. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Молескин пиджак.*

МОЛИБДЕ'Н *и. хим.* Көмеш сыман ак ялтыравыклы каты металл. *Норвегия рудникларында молибден, хром, никель чыгарыла.* Ссц. Тат.

МОЛЛЮСК *и. зоол.* Күбесенчә кабырчык эчендә яши торган, умырткасыз йомшак тәнле хайван. *Диңгез моллюсклары.* □ *Диңгезләрдә йөзгән пароходка моллюскларның ябыша.* Х. Камалов.

МО'ЛНИЯ *и.* 1. *махс.* Телеграмманың бик ашыгыч төре. *Молния алдым, кайтырга чакыралар.* Сов. әд. [*Фәнис:*] *Ике атналык эшне биш көндә! Молния белән бүген үк редакциягә хәбәр итәм.* Г. Минский.

2. Стена газетасының бик ашыгыч чыгарылып, көндәлек тормыштагы иң мөһим мәсьәләләрне яктыртып бара торган төре.

3. Киемдә төймә, каптырма кебек нәрсәләрне алмаштыра торган җайланма.

МОЛОДЕ'Ц *хәб. сүз. сөйл.* Мактауны, хуплауны белдерү өчен кулланыла.— *„Чулпан"нар сугышның иң кыен вакытында да сынатмыйлар, молодец алар, дисеннәр!* Г. Бәширов.

МОЛОТИ'ЛКА *и. а.-х.* Ашлык сугу машинасы. *Молотилка тузан күтәреп бодай суга башлады.* Г. Гобәй.

МОЛЬБЕРТ *и.* Эш вакытында рәссамның киндерле рам куя торган җайланмасы.— *Буяуларым, мольбертым биредә булса, мин кыз рәсемен ясар идем.* Г. Әпсәләмов. *Мастерскойдагы мольбертта минем яңа картинам тора.* Х. Якупов.

МОМЕНТ *и.* **1.** Нинди дә булса эш, күренеш, хәрәкәт була, башкарыла торган бик кыска вакыт арасы; мизгел. *Бу моментта Каюм, чокыр уртасында торып, тирә-якны җентекләп караштыра иде.* Ш. Камал.

2. Нәрсәнең дә булса үсешендә бер этап, чор. [*Якуб*] *пароходстводагы хәлләрне сорашырга тотынды: большевиклар күпме, оешканнармы, — пароход командирлары Вакытлы хөкүмәткә ничек карыйлар, моментны аңлыйлармы?* И. Гази.

3. *сөйл.* Нинди дә булса күренешнең, хәлнең һ. б. ш. аерым бер ягы. *Шәрәфи сөйли, аның алдында авыл белән каланың багланышлы моментлары ачыла торалар.* Г. Ибраһимов. *Хәсәновны мөдир итеп билгеләгән чагында бер моментны исәпкә алмаганнар.* Сов. әд. || Нинди дә булса эш өчен уңай очрак, җай, форсат. *Без моменттан файдаланырга, кирәкле мәгълүматлар алырга тиеш идек.* Ә. Айдар. *Момент туры килү белән, партизаннар мине фронт аша үзебезнең якка чыгардылар.* Р. Ишморат.

4. *сөйл.* Фактор, факт. *Либреттода очраклы хәлләр фабуланы төзүче хәлиткеч момент булып торалар.* М. Җәлил.

5. Художество әсәрләрендә берәр вакыйга, хәл һ. б. ш. эченә алган эпизод, күренеш. *Постановкада ышандырмый торган тышкы эффектка корылган, тирән уйланмаган моментлар да бар.* М. Җәлил. [*Әсәрдә*] *асраулар өстәлгән, вәгазьлелек бик нык киметелеп, комик моментлар көчәйтелгән.* М. Гали.

6. *рәв. мәгъ. сөйл.* Бик тиз, хәзер үк. [*Илдар:*] *Сусынны момент басабыз аны, Искәндәр абый.* Г. Гобәй.

МОНАЗАРА *и. иск. кит.* Бәхәс, сүз көрәштерү, дискуссия, диспут. *Гайсалар утырган якка чыксам, анда бик куәтле моназара башланган икәнен күрдем.* Ф. Әмирхан. [*Хәлфә:*] *Бай әфәнде, мондый гыйльми моназараларны чыгару яхшы эш булды.* Г. Газиз.

МОНАЗАРАЧЫ *и.* Бәхәсләшүче, сүз көрәштерүче. [*Абелкарип:*] *Без моназарачылар түгел, моназарада нишләп йөрик.* Т. Гыйззәт.

МОНАЗИР, МОНАЗЫЙР *и. иск. кит. к.* моназарачы. *Бу елларда Зыя мәдрәсәнең пишкадәмнәреннән булган бер моназыйр илә бик чынлап якынлашты.* Г. Ибраһимов.

МОНАР *и. диал. к.* рәшә. *Биек тауның үләне — Башын монар алганы.* Н. Исәнбәт.

МОНАРЛАНУ *ф. диал.* Һаваның куерып, зәңгәрләнеп һәм ерактан болыт төсле булып күренүе; томан, рәшә төшү. *Кызды һава монарланып* [*куерып*], *Кыр белән дала чобарланып.* Дәрдмәнд.

МОНАРЛЫ *с. диал.* Рәшәле.

МОНАРХ *и.* Мөстәкыйль идарә итүче власть башлыгы (патша, король, император һ. б. ш.).

МОНАРХИЗМ *и.* **1.** Дәүләт властеның бердәнбер формасы — монархия дигән каршта торган реакцион-политик юнәлеш.

2. *к.* монархия. [*Француз*] *монархизмына каршы либераль буржуа фикерләр (кафеларда оешкан беренче ячейкаларда) үскән.* Г. Гали.

МОНАРХИСТ *и.* Монархизм тарафдары, монархия яклы кеше, монархияче. [*Газета*] *татар монархистлары, татар кадетлары тарафыннан оештырылган „Иттифакы мөслимин“ җәмгыятенең, мәкәрҗә съездларының чын йөзен ачып бирергә тырыша.* М. Гали.

МОНАРХИ'СТИК *с.* Монархизм һәм монархиягә мөнәсәбәтле. [*Мансуров*] *монархиягә, монархистик партияләргә каршы революцион эш өчен армас көрәшүче.* Г. Нигъмәти.

МОНА'РХИЯ *и.* Бер генә кеше — монарх тарафыннан идарә ителә торган деспотик дәүләт идарәсе формасы һәм шундый идарә формалы хөкүмәт. [*1903—1905 еллар*] *Россиядә кара монархия хөкем сөрүе һәм илне каплап алган промышленность кризисы нигезендә илдә эшчеләр хәрәкәтенең күтәрелүе белән характерлы.* М. Җәлил.

МОНА'РХИЯЧЕ *и. к.* монархист. *Монархияче офицерлар.*

МОНАСТЫРЬ *и.* **1.** Үзенең җире, капиталы булган, монахлар яки монашкалар общинасыннан гыйбарәт чиркәү оешмасы. *Әллә нидә бер күрше авыллардан бөкрәеп беткән ярым сукыр карчыклар килгәндә генә, монастырь эче бераз җанлана.* К. Нәҗми. || *җый.* Шул община членнары.

2. Шул община карамагындагы чиркәү, торак йортлар һәм территория.

МОНАФИКЪ *с. иск.* Икейөзле, усал, эчкерле (кеше).

МОНАФИКЪЛЫК *и. иск.* Монафикъ кешегә хас сыйфатлар: икейөзлелек, усаллык, эчкерлелек.

МОНАХ *и.* Монастырьда яшәп, монастырь уставының талəпләре буенча аскет тормышы алып баручы чиркәү общинасы члены. *Караңгы бүлмәләр, агач орнамент белән эшләнгән иконалар, гравюралар урта гасыр монахларының тормышларын искә төшерәләр.* Г. Гали. || *күч. сөйл.* Дөньяның барлык рәхәтеннән ваз кичеп яшәүче ир кеше.

МОНАХЛЫК *и.* Монах булу; монах тормышы. || *күч. сөйл.* Дөньяның барлык рәхәтеннән ваз кичеп яшәү хәле.— *Сез бүген мине аскетлыкта гаеплисез, көлеп, мыскыллап, монахлыкка язылырга тәкъдим итәсез.* А. Шамов.

МОНГОЛ *и.* Монголия Халык Республикасында һәм Эчке Монголиядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. || *с. мәгъ.* Монголга мөнәсәбәтле. *Монгол теле. Монгол хатын-кызлары.* || *с. мәгъ.* Монголга охшаган, монголга хас булган. *Безнең янга монгол кыяфәтле бер гаскәри килеп басты.* Ш. Усманов.

МОНГОЛЛЫК *и.* Монголларга хас сыйфатлар. *Егет йөзендә монголлык күренсә дә, саргылт чәчле, ерш белән алынган башы ачык булганлыктан, табигый, мин моны татар булыр дип хәтеремә дә китермәдем.* Ф. Әмирхан.

МОНГОЛО'ИД: монголоид раса — дөньядагы өч расаның берсе, Азиядә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәк өлешен ала. *Азиянең һәм Американың кайбер халыклары (кытайлар, бурятлар, индеецлар, монголлар) саргылт тәнле монголоид расасына керәләр.* Биология.

МОНДА *а.* „Бу“ алмашлыгының урын-вакыт килеш формасы. || *рәв. мәгъ.* Бу урында, биредә. *Әз генә күземне йомсам, анда да син, монда да син.* Ф. Бурнаш. || Бу урынга, бирегә. *Тукта әле, тукта, капка бикле булгач, син ничек монда керә алдың, кем кертте сине?* К. Тинчурин.— *Насыйп булса, ошбу хатны алгач та, бик тизлек белән, кулыңда күпме*

акча бар, барлыгын җыеп, монда җибәр. Ш. Мөхәммәдев.— *Сания! Райбашкарма председателенә шалтырат, монда керсен иде.* Г. Бәширов. || Бу мәсьәләдә; бу очракта. *Минем катнашым юк монда, әнә картлар җыйган җыен, алардан сора.* М. Әмир. [*Рәхимә:*] *Мин университетта укыганда йөзү ярышларында катнашкан кеше дә, ләкин монда мәсьәлә икенче төрлерәк булды шул.* А. Әхмәт.

МОНДАГЫ *с.* **1.** Бу урындагы, биредәге. *Туктаусыз яуган кар мондагы сукмакны күмеп киткән.* Г. Ибраһимов. *Кил син, рәссам, шушы төшләргә, Күр мондагы таңнар атканын.* Ш. Маннур.

2. Бу урында туып-үскән яки озак яшәгән.— *Чынлап, абзый, аңлый алмадым; мин бит, абзый, мондагы кеше түгел.* Г. Камал. || Урындагы, җирле (оешмалар турында).— *Безнең мондагы губисполком Терентьев бер атнадан бирле Мәскәүдә.* Ш. Камал.

МОНДЫЙ *күрс. а.* **1.** Нәрсәнең дә булса сыйфатына ишарә итә: моның кебек, моның шикелле. *Мондый каты газапны беренче мәртәбә татучы Илсөярнең сыны катты, минутка якын тын ала алмыйча ятты ул.* Г. Гобәй. *Мондый күкеле сәгатьләр белән яшәве бигрәк тә күңелле булыр иде.* Д. Аппакова.

2. Гомумиләштерүче сүз буларак кулланыла. *Җыелышта мондый мәсьәләләр каралды.*

МОНЕ'ТА *и. сөйл.* Металл акча. *Монета сугу дәүләт кулында тупланган.* Политэкономия. || *җый.* Гомумән акча.

МОНИЗМ *и. филос.* Дөньяның һәм андагы күренешләрнең нигезендә бер генә башлангыч — я рух, я материя ята дип раслый торган философик караш; *киресе:* дуализм.

МОНИСТ *и. филос.* Монизм тарафдары.

МОНИ'СТИК *с. филос.* Монизмга мөнәсәбәтле; монизм белән сугарылган. *Тарихка монистик караш.*

МОНИТОР *и.* **1.** Диңгез яки елганың сай җирендә торып, яр буендагы объектларны һәм ярга якын җирдә урнашкан дошман корабльләрен җимерү өчен эре калибрлы артиллерия белән коралланган бронялы хәрби корабль. *Диңгез мониторы. Елга мониторы.*

2. *махс.* Җир катламнарын һәм тау токымнарын көчле су агымы белән юдырып эшкәртә торган җайланма.

МОННАН *а.* „Бу“ алмашлыгының чыгыш килеш формасы. || *рәв. мәгъ.* Бу урыннан, биредән. *Моннан бер йөз метрлар уңдарак разведчиклар кыя битендә чытырман куаклык эзләп тапканнар.* И. Гази. *Моннан кырык чакрым, Сакмар суы буенда, Кигәвенле авылы бар.* Ш. Камал. || Бу хәлдән, бу мәсьәләдән, бу очрактан. *Юк, моннан болай гына котыла алмыйсың син, Нәфисә.* Г. Бәширов.— *Әгәр дә бу эш хакында мин үзем гаепле булсам, моннан котылырга бер юл табарга кирәк.* Г. Камал. || Вакытны белдерә торган сүзләр белән бергә килгәндә: шушы моменттан. *Моннан 3—4 сәгать элек.* □ *Мостафа моннан берничә көн элек бу тегүченең авырып егылганын ишеткән иде.* Г. Ибраһимов. *Мостафин моннан өч ел элек Байгузиннарның бердәнбер кызларына өйләнде.* Ә. Еники.

Моннан ары (болай, соң) — 1) яңадан, кабат, киләчәктә, башка вакытта.— *Син бутама, карчык, эшне моннан ары, яме?* Ә. Фәйзи. *Ул әнисе сүзләреннән Маратның моннан болай гел үзләрендә торасын гына аңлады.* Г. Гобәй.— *Әниеңә әйт, моннан соң борчак оны җибәрмәсен.* Т. Гыйззәт; 2) соңыннан. *Моннан соң тиз генә кайтып китәргә дип хәл иттеләр.* Каз. утл.

МОНО- Кушма сүзләрдә „бер“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **монотеизм, монохроматик, монокультуралы, монорельслы.**

МОНОГА'МИЯ *и. этн.* Никахның бары тик бер хатын (ир) белән тору формасы.

МОНОГРА'ММА *и.* Ике яки берничә хәрефне бергә үргәндәй укмаштырып язу формасы. || Шундый юл белән язылган шартлы билге яки инициаллар, сүзләр. *Мин алгачтан, [Гайса] портсигарның күп монограммалар ябыштырылган аскы ягын өскә әйләндереп куйды.* Ф. Әмирхан. [*Өч артистка да*], *көмешчедән монограмма яздырып, алтынланган жетон бүләк итәргә карар чыгардык.* Каз. утл.

МОНОГРА'ФИК *с.* Монографиягә мөнәсәбәтле. *Монографик тикшеренү. Монографик планда язылган хезмәт.*

МОНОГРА'ФИЯ *и.* Аерым бер мәсьәләне, теманы тикшерүгә багышланган фәнни хезмәт. *К. Нәҗми иҗаты турында монография.* □ *Рәхим кулына өйдә укылырга тиешле монографияне алды.* А. Расих.

МОНОКЛЬ *и.* Бер күзнең чокырына җайлап куеп күзлек яки пенсне урынына кулланыла торган оптик пыяла. *Килеш-килбәтең дә әйбәт кенә, Монокль дә килешә үзеңә.* Һ. Такташ. *Монокль кигән, зәһәрлегеннән иреннәре чалшайган Чемберлен карикатурасына бер эшче агай бармагы белән күрсәтеп тора: ул гаепле.* И. Гази.

МОНОКУЛЬТУ'РА *и. а.-х.* Бер культураны берничә ел буена рәттән бер үк кырда игү. *Авыл хуҗалыгының бер яклы үсеше (монокультура дип атала торган хәл) бөтен-бөтен илләрне чимал сатып алучы монополистлар башбаштаклыгына дучар итә.* Политэкономия.

МОНОЛИТ *и. кит.* **1.** Бер бөтен зур таш. || Шундый ташны чокып ясалган предмет.

2. *с. мәгъ. күч.* Бердәм, таркалмаслык, нык; көчле. *Монолит коллектив. Монолит бердәмлек.*

МОНОЛИТЛЫК *и.* Монолит булу сыйфаты. *Тау токымының монолитлыгы. Партиянең политик монолитлыгы.*

МОНОЛОГ *и.* Пьесада, шулай ук проза әсәрләрендә персонажның үз-үзенә, башка персонажларга яки тамашачыларга мөрәҗәгать итеп сөйләгән сүзләре. *Ядкарь хан монологы.* М. Җәлил. [*„Бәхетсез егет“ әсәре*] *күбрәк озын-озын монологлардан тора.* М. Гали. *Минем кесәмдә бары бер сум гына акчам барын парикмахерга белдергәч, безнең арада озак диалог, монологлар булып алды.* Һ. Такташ.

МОНОЛО'ГИК *с.* Монологка мөнәсәбәтле. *Монологик сөйләм.*

МОНОМЕТАЛЛ: монометалл система — *к.* монометаллизм. *Капиталистик илләрнең барысы да диярлек монометалл системага — акча әйләнешенең алтын системасына күчкәннәр.* Политэкономия.

МОНОМЕТАЛЛИЗМ *и.* Акча әйләнешенең нигезендә бары бер төрле металл (алтын яки көмеш) гына йөртелә торган акча системасы.

МОНОПОЛИСТ *и.* **1.** Берәр өлкәдә монополия белән файдаланучы кеше.

2. Эре капиталист, монополистик капитал вәкиле.

МОНОПОЛИ'СТИК *с.* **1.** Монополия принципларына нигезләнгән. *Монополистик капитал.* □ *Монополистик капитализм яки империализм — капитализмның югары һәм соңгы стадиясе.* Политэкономия.

2. Монополия формасында булган. *Монополистик оешма.*

МОНОПО'ЛИЯ *и.* **1.** Берәр нәрсәне җитештерү яки сату өчен берәр кешегә, төркемгә яки дәүләткә бирелгән чиксез хокук. *Тышкы сәүдә монополиясе.*

Корыч җитештерү монополиясе. □ *Борынгыча — бабайларча әш йөртеп килгән татар сәүдә капиталы чәй монополиясен кулдан ычкындыра.* И. Рәмиев. || *күч. сөйл.* Берәр нәрсәдән файдалану өчен бирелгән хокук; берәр өлкәдә башкалар белән чагыштырганда өстенлек, беренчелек.

2. Хуҗалыкның берәр өлкәсендә хакимлек итү һәм максималь табыш алу өчен капиталны концентрацияләү нигезендә барлыкка килгән әре капиталистик берләшмә. *Капиталистик монополияләр. Монополияләр көрәше.*

МОНОПО'ЛИЯЛЕ *с. к.* монополистик. *Монополияле сәүдә.* || *күч. сөйл.* Нинди дә булса өлкәдә монополия яулап алган. [*Виктор:*] *Шәһәрдә без антенналар кую әшенең монополияле белгечләре идек.* Р. Төхфәтуллин.

МОНОПО'ЛИЯЛӘШТЕРҮ *ф.* Берәр нәрсәгә монополия урнаштыру. *Тышкы базарны монополияләштерү.*

МОНОПО'ЛИЯЛӘШҮ *ф.* 1. Берәр нәрсәгә монополия урнаштыру буенча берләшү. *Монополияләшкән тармаклар башка тармакларга карата привилегияле хәлдә булалар.* Политэкономия.

2. Нәрсәгә дә булса (мәсәлән, әйбер эшләп чыгаруга, товарга һ. б.) монополия урнашу.

МОНОПО'ЛИЯЧЕ *и. кит. к.* монополист.

МОНОПОЛЬ *с. к.* монополистик (1 мәгъ.) *Монополь урын. Монополь хокук.*

МОНОТИП *и. полигр.* Типографиядә: хәрефне аерым литерлар формасында коеп җыя торган машина.

МОНОТОНЛЫ *с.* Бер генә тонда булган, бертөрле, үзгәрешсез. *Монотонлы тавыш.*

МОНОТОНЛЫЛЫК *и.* Монотонлы булу сыйфаты. *Хикәядә ара-тирә монотонлылык та сизелә.* Каз. утл.

МОНОФТОНГ *и. лингв.* Ике элементка бүленми торган сузык аваз.

МОНПАСИ, МОНПАСЬЕ *и.* Суыра торган әчкелтем каты конфет төре, „пыяла конфет". [*Кибеттә*] *монпасье, чикләвек, крендель шикелле әйберләр дә тулып ята.* Ш. Камал. *Пешкән чәкчәкне подноска баллап катыралар, өстен төрле монпаси белән бизиләр.* С. Сүнчәләй.

МОНТАЖ *и.* 1. *тех.* Машина, корылмаларны билгеле бер план һәм сызым буенча җыю, кору эше. || Шундый эшкә мөнәсәбәтле. *Монтаж мастерское.*

2. Фильмның, әдәби яки музыкаль әсәрнең аерым кисәкләреннән әчтәлеге һәм художество эшләнеше ягыннан бер бөтен әсәр җыю (тудыру, оештыру, булдыру). *Музыкаль монтаж.* □ [*Укучылар*] *„Җиңеп кайт, әти!" дигән әдәби монтаж төзеделәр.* Г. Гобәй.

МОНТАЖЛАУ *ф.* Монтаж эшләрен алып бару. [*Инженер Бакинский*] *вышкаларны әре блоклардан монтажлау методын эшләп бетереп ята.* И. Гази.

МОНТАЖЛАУЧЫ *и.* Монтажлау эшен башкаручы, монтажчы.

МОНТАЖЧЫ *и. махс.* Монтаж (1 мәгъ.) эшен башкаручы, монтажлау буенча белгеч. *Төзелеш мәйданнарында балта осталары һәм ташчылар урынына тиздән монтажчылар эшли башлар.* Чаян.

МОНТАР *и. иск.* Киртә, каршылык. *Аккан суга монтар юк.* Мәкаль.

МОНТЕКРИ'СТО *и.* Вак калибрлы мылтык һәм пистолетлар системасы; шул системадагы мылтык, пистолетларның гомуми исеме.

МОНТЁР *и.* Электр үткәрү, ремонтлау эшләре буенча белгеч; электромонтёр. *Монтёрлар баганалар башында трамвай, электр чыбыкларын ялгап тора-лар.* К. Тинчурин.

МОНТЁРЛЫК *и.* Монтёр булу; монтёр эше, һөнәре.— *Син анда монтёрлыкка өйрәнергә тырыш.* Г. Әпсәләмов.

МОНУМЕНТ *и. кит.* Зур тарихи вакыйга яки бөек шәхесләр хөрмәтенә салынган архитектура яки скульптура корылмасы; һәйкәл. || Үлгән кешегә истәлек итеп кабер өстенә гранит яки мәрмәрдән куелган язулы корылма. *Кабер өсте монументы.* || *с. мәгъ. к.* монументаль. *Монумент бина. Монумент һәйкәл.*

МОНУМЕНТАЛЬ *с.* 1. Бик зур булуы, мәһабәтлеге белән тәэсир ясый торган. *Монументаль корылма.* □ *Электәге искереп беткән бер-ике катлы йортлар урынында монументаль җәмәгать биналары тезелеп киткән.* Сов. әд.

2. *күч.* Бик зур, җитди һәм тирән эчтәлекле. *Монументаль хезмәт.*

3. *юг.* Мәһабәтлеге белән аерылып тора торган. *Монументаль сын.*

МОНУМЕНТАЛЬЛӘШҮ *ф. кит.* Монументаль (1 мәгъ.) хәлгә килү. *Образ күзгә күренеп зурая, монументальләшә бара.* Ф. Миңнуллин.

МОПС *и.* Зур башлы, яньчек борынлы, кыска куе йонлы бүлмә эте.

МОПЕД *и.* Велосипедның мотор ярдәмендә хәрәкәт итә торган төре. *Хәзер һәркемне — автомобиль, мотоцикл, мопед йөртүчеләрне — яңа кагыйдәләр белән таныштыру бик әһәмиятле.* Соц. Тат.

МОРАД *и. кит. к.* максат. *Сабыр иткән морадына җиткән.* Мәкаль.— *Менә шул морадыма ирешү өчен мин бүген язган мәктүбемне бирмәкче булам.* Т. Гыйззәт.

МОРАЛЬ *и.* 1. Кешеләрнең үзара һәм җәмгыятькә мөнәсәбәтләрендәге әдәп нормалары һәм принциплары җыелмасы; әхлак. *Коммунистик мораль.* □ [*М. Гафури шигырьләре*] *реакциягә, буржуазия мораленә каршы юнәлтелгән.* М. Җәлил. *Кешенең хезмәткә социалистик мөнәсәбәте мәсьәләсе, мәҗбури рәвештә, аның әхлагы, морале мәсьәләсен дә үз эченә алырга тиеш.* Х. Госман.

2. Нәрсәдән дә булса гыйбрәт, гыйбрәтле нәтиҗә. *Гадәттә, һәр мәсәлнең була морале.* Г. Минский.

3. *сөйл.* Үгет-нәсихәт.— *И эни, юкка телеңне әрәм итеп мораль укыйсың.* Э. Касыймов.

4. *с. мәгъ.* Мораль, әхлак турындагы, моральгә, әхлакка бәйле. *Мораль принциплар.* □ *Җыентыкка кергән мәсәлләрнең бер өлеше Тукайның үзе язып кушкан мораль нәтиҗә чыгарулары белән очланганнар.* Г. Нигъмәти. || Эчке, рухи. *Мораль ярдәм.* □ *Без көн саен коммунизм төзүченең мораль йөзе турында сөйлибез.* Г. Әпсәләмов.— [*Эти-әниләргә*] *барсам, физик яктан да, мораль яктан да чын-чынлап ял итеп кайтам.* М. Җәлил.

МОРАЛЬЛЕК *и. к.* мораль (3 мәгъ.). [*Тәнкыйтьче әфәнде*], *„Гафури укырга, әхлакка өнди" дип, шигырьне шул коры моральлек җәһәтеннән тәкърир итә (бәяли).* Ф. Әмирхан.

МОРАЛЬ-ПОЛИ'ТИК *с.* Нәрсәнең дә булса мораль һәм политик нигезен тәшкил иткән. *Совет халкының мораль-политик бердәмлеге.*

МОРГ I *и.* Мәетләр куя торган бүлмә яки бина.

МОРГ II *и.* Польша һәм Литвада якынча 0,5 гектарга тигез булган җир үлчәве.

МОРДАР *и. иск.* 1. Үләксә.

2. *күч.* Кабахәт, пычрак, шакшы кеше. *Кулга алып мылтыкларны, сафларга басарбыз. Дошманнардан, мордарлардан үчләрне алырбыз.* Э. Исхак.

‖ *с. мәгъ.* Кабахәт, пычрак, шакшы. *Үз гөнаһын башкалар өстенә аудару — иң мордар, иң әшәке кешеләрнең эше.* Дәрдмәнд.

◊ **Мордар китү** — 1) *дини.* Имансыз үлеп китү, үзен-үзе үтерү.— *Юк, юкI.. Мордар киткән кешене өебезгә кертер хәлем юк.* Т. Гыйззәт; 2) әрәм булу, вакытсыз әрәм булу. *Кассап (мал суючы) күп булса, хайван мордар китәр.* Мәкаль.

МОРДАРЛЫК *и. иск.* 1. Мордар булу.

2. *күч.* Кабахәтлек, пычраклык, шакшылык. *Ул нинди генә эшкә, нинди генә мәслихәткә катышмасын, һәрвакыт уйлаганы җәбер-золым, эшләгәне бозыклык, мордарлык иде.* Ш. Мөхәммәдев.

МОРДВА *и.* Мордва АССРда яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе. *Мордва хатыны. Мордва кызы.*

МОРДВА'ЧА *рәв.* Мордва телендә.

МОРЕ'НА *и. геол.* Бозлыклар белән шуышып төшкән тау токымнары, зур-зур таш өемнәре. *Мореналар җир өстендә озын-озын калкулык формасындагы ятымнар хасил иткәннәр.* Сов. әд.

МОРЖ *и. зоол.* 1. Кыска куе йонлы, ишкәк аяклы, зур-зур казык тешле, озын мыеклы, зур гәүдәле имезүче диңгез хайваны. *Тын океан моржы. Ана морж.* □ *Боз өстендә ак аюлар уйный, симез тюленьнәр шаяра, озын тешле моржлар ял итә.* А. Алиш.

2. *күч.* Кыш көне бозлы суда (бәкедә) коенучы кеше.

МОРЗА *и. к.* мирза (1 мәгъ.). *Алар бар да хан кызының кулын өмет иткән, бәхетләрен сынарга чыккан морза егетләре.* Н. Исәнбәт. *Тик бармам, җаный, бармам Хәмит морза кулына, Зифа буемны салмам Аның пычрак куенына.* Ш. Маннур.

МОРЗЕ: морзе аппараты — Морзе әлифбасы белән сигналлар тапшыру өчен иң гади төзелешле телеграф аппараты. *Морзе аппараты янында бер яшь егет утырган.* Ш. Усманов. **Морзе әлифбасы** — телеграф буенча хәреф һәм саннарны тапшыру өчен шартлы билгеләр системасы.

МОРО'ЖЕНОЕ *и.* Каймак, сөт, җиләк суы һ. б. ш. тундырып хәзерләнгән татлы ашамлык.

МОРО'ШКА *и. бот.* Сазлыкта үсә торган үлән үсемлек яки ак чәчәкле ярым куак үсемлек һәм шуның җиләге. *Кайчакта биек үлән арасында төньякның җир җиләге — морошка очрый иде.* Г. Әпсәләмов.

МОРС *и.* Җиләк-җимеш суларыннан ясалган салкын эчемлек.

МОРТИ'РА *и.* Кыска көпшәле туп. *Кыр мортирасы. Яр буе мортирасы.* ‖ *с. мәгъ.* Мортирага мөнәсәбәтле. *Мортира батареясы.*

МОРФЕ'МА *и. лингв.* Сүзнең лексик яки грамматик мәгънәгә ия булган кисәкләре (тамыр, кушымча яки алкушымча).

МО'РФИЙ *и. фарм.* Авыртуны вакытлыча баса һәм йоклата торган наркотик матдә (билгеләнгән дозадан артык кабул иткәндә агулый). *Больницада [Зиннуровка] ашыгыч медицина ярдәме күрсәткәннәр: кабат морфий, атропин, кардиамин уколлары ясаганнар, кислород сулатканнар.* Г. Әпсәләмов.

МО'РФИЙЧЫ *и.* Морфинизм белән интегүче кеше.

МОРФИНИЗМ *и. мед.* Морфий куллану белән мавыгудан гыйбарәт авыру; наркоманиянең бер төре.

МОРФИНИСТ *и. к.* морфийчы.

МОРФОЛО'ГИК *и. лингв.* Морфологиягә мөнәсәбәтле. *Морфологик тикшеренүләр. Сүзгә морфологик анализ ясау.*

МОРФОЛО'ГИЯ *и.* 1. Организмнар, органнар һәм туфрак төзелеше турындагы фән. *Эксперименталь морфология.* ‖ Организмнар, органнар һәм туфрак төзелеше. *Бактерияләр морфологиясе. Үсемлек сабагының морфологиясе.*

2. *лингв.* Нинди дә булса телдә сүзләрнең үзгәрү формалары системасы; шулай ук грамматиканың сүз формаларын өйрәнә торган бүлеге. *Татар теле морфологиясе.*

МОРЯК *и. сөйл.* 1. Флотта хезмәт итүче, диңгезче. *Хәрби моряк. Сәүдә флоты морягы.* □ *Яшь морякның күкрәгендәге значоклары хәрби эштә осталыгын, политик белемдә алдынгылыгын күрсәтеп торалар.* А. Әхмәт.

2. Диңгез эшендә тәжрибәсе булган, диңгезне бик яхшы белүче кеше, диңгезче. *Разведка начальнигы Микита — карт моряк алдан бара.* Г. Гобәй.

МОРҖА *и.* 1. Мичнең түшәм аша өй түбәсеннән өскә таба күтәрелгән, төтен чыга торган өлеше.— *Син хатының Өммегөлсемгә әйт, моржасының корымын ешрак чистартып торсын.* Г. Әпсәләмов. ‖ Пароход, паровоз һ. б. ш. төтен чыга торган җайланмасы. *Заводларның биек моржалары Кайнар сулыш чәчә һавага.* Ш. Маннур. *Чирек сәгатьтән соң пароход күздән югалып, моржасыннан чыккан кара төтен генә сызылып күренәктә иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Нечкә моржалы паровоз теплушканы китереп туктатты. Ш. Усманов.* ‖ *диал.* Самовар кайнатканда, аны мичнең төтен юлына тоташтыра торган торба. *Гайнижамал, кайнап чыккан самоварның моржасын алып, аның капкачын --- бер читен ачык калдырып, кыйшайтыбрак куйды.* Ш. Камал. ‖ *диал.* Лампа пыяласы, лампа куыгы. *Лампаның моржасы челтер-челтер килә, Хәдичә әледән-әле „уф" дип авыр сулап куя иде.* Г. Бәширов.

2. *диал.* Мич. *Моржа акшарлау.*

Моржа капкачы — моржадан салкын һава кермәсен һәм мичнең җылысы чыкмасын өчен төтен юлын яба торган җайланма. **Моржа тазартучы** — *к.* моржачы. [*Гыймади:*] *Мин монда хәзерге көнне сторож да, дворник та, ат караучы, су ташучы, моржа тазартучы да.* Ә. Фәйзи.

◊ **Моржадан очу** — бөлгенлеккә төшү, банкрот булу, банкротлыкка калу.— *Ирләрегез моржадан очкач, фирманы исемегезгә күчерергә мәҗбүрме?* М. Фәйзи. **Моржадан төтен чыгару** — башкалар рәтеннән, башкалар кебек үк тереклек итү, тормыш алып бару.— *Кыярыңны каравылла да, моржаңнан төтен чыгар.* А. Шамов.

МОРЖАЧЫ *и.* Мичнең төтен юлларын тазартучы кеше. *Минем әтием гомер буе моржачы булган.* Г. Галиев.

МОСАФИР *и. иск.* 1. Юлчы. [*Шәпеш:*] *Бездә, Җаекта, мосафирларны хөрмәт күрсәтми җибәрү гадәте юк.* Ә. Фәйзи. [*Вахитов*], *ишек, бусагаларга лампа яктысын төшерергә тырыша биреп,* [*төнге мосафирларны*] *әчкә алып керде.* Г. Ибраһимов.

2. Узгынчы. [*Шәйхезаман:*] *Сез кайдан, мосафирмы, мөһаҗирмы (чит илгә күчеп баручымы), әфәндем?* Т. Гыйззәт.

МОСАФИРХАНӘ *и. иск.* Юлчылар өчен номерлар; гостиница. *Мосафирларга хаслап салдырылган мосафирханәгә барып төштек.* М. Гафури.

МОСКА'ТЕЛЬ *җый. и.* Сату өчен билгеләнгән буяу, җилем һ. б. ш. химик әйберләр. ‖ *с. мәгъ.* Москатель булып исәпләнә торган. *Москатель товарлары.* ‖ Москатель белән сәүдә итә торган. *Москатель кибете.*

МОСКА'ТЕЛЬЧЕ *и.* Москатель товарлары сатучы.

МОСКИТ *и. зоол.* Көньяк илләрдә: бик каты тешли торган канечкеч вак бөҗәк. [*Борынмөгезләрнең*] *дошманнары бөгәлчәннәр, москитлар. Чиксез күп*

саннлы бөҗәкләрнең тешләве аларны котырындыра. Соц. Тат.

МО'СТИК *и.* 1. *махс.* Ясалма тешләр беркетелә торган планка.

2. *спорт.* Гәүдәне артка каерып, күкрәкне һәм корсакны өскә таба күтәргән килеш аяк-куллар белән җиргә таянып торудан гыйбарәт гимнастик фигура.

3. Судноларда капитан басып тору өчен, кайбер машиналарда нәрсәне дә булса күзәтү яки командалык итү өчен махсус күтәренке урын яки вышка, капитан күперчеге. *Пароходның кызыл путалы кара моржасы, мостикка чыгып баскан ак кительле, ак фуражкалы юан капитаны күренә.* И. Гази.

МОСТОВОЙ *и. сөйл.* Урамның таш түшәлгән яки асфальт җәелгән ат, машина һ. б. йөри торган өлеше. *Урамда таш мостовойдан чакылдап үткән ат дагаларының тавышлары сирәкләнгәннән-сирәкләнә бара иде.* Ш. Камал.

МОСЬЕ *и.* Французларда ир кешегә хөрмәтләп мөрәҗәгать итү сүзе. || *сөйл. иск.* Тәрбияче-гувернёр француз.

МОТИВ *и.* 1. *кит.* Берәр нәрсә файдасына дәлил, аргумент. [*Дунаев әлеге ике кешегә:*] *Сез кичке заседаниегә килегез, шунда үзегезнең мотивларыгызны әйтерсез, — диде.* Ш. Камал.

2. Сәнгать әсәре сюжетының бер элементы. [*Әсәрнең*] *көрәш һәм батырлык темасы Рәйханәнең кызганыч язмышы, фаҗигале үлеме мотивлары белән аралашып бара.* М. Җәлил. [*Г. Камал*] *әсәрләренең әхтәлеге революцион пафос һәм сыйнфый көрәш мотивлары белән сугарылды.* М. Гали.

3. Нәрсәнең дә булса нигезенә алынган үрнәк, сюжет. *Халык мотивлары буенча чигү.* □ *„Ленин“ әсәре „Ленин 1918 нче елда“ дигән картинадагы мотивлар буенча язылган.* Татар театры тарихы.

МОТИВЛАШТЫРУ *ф.* Дәлилләү, нигезләү. *Әсәрдә күрсәтелгән вакыйгалар, егетнең фикер үсешендәге, тормыш үзгәрешендәге күренешләр барысы да мотивлаштырусыз, сәбәбе билгесез итеп бирелгәннәр.* Г. Нигъмәти.

МОТЛАК *рәв. иск.* Һичшиксез, абсолют рәвештә, һичсүзсез. *Шөбһә юк, мотлак, хәрамдыр йоклап яту.* М. Гафури. [*Сабит:*] *Вөҗданым белән вәгъдә бирәм, сезнең билгеләгән җәзагыз никадәр зур булса да, мин аны мотлак кабул итәмен.* М. Фәйзи.

МОТЛАКАН *рәв. иск.* Һичшиксез, һичсүзсез, һичнәрсәгә карамастан. *Милләтнең артта калуы турында сүз ачылса, Хөсәен мотлакан ул фикергә иштирак итә (кушыла).* Ф. Әмирхан.

МОТО- Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) моторлы, мәсәлән: **мотобот, мотодрезина, мотокаток;** 2) моторлаштырылган, моторлы машиналар белән тәэмин ителгән, мәсәлән: **мотодивизия, мотоколонна;** 3) мотоцикл(ет)ларда үткәрелә торган, мәсәлән: **мотоспорт.**

МОТОР *и.* Һәртөрле энергияне механик көчкә әйләндерә торган машина, двигатель. *Автомобиль моторы. Моторны кабызу.* □ *Гөлсем трактор моторының эшләвен күзәтеп тора иде.* Г. Бәширов.

МОТОРИЗА'ЦИЯ *и.* Моторлаштыру эше, моторлы машиналар белән тәэмин итү эше.

МОТОРИ'КША *и.* Кешеләр утыртып йөрү өчен өсте япмалы, өч көпчәкле мотоцикл. *Соңгы вакытта Һиндстан урамнарында моторикшалар күренгәли башлаган иде.* Каз. утл.

МОТОРИСТ *и.* Моторлы машинада эшләүче. *Ул сугышка чаклы тегермәндә мотторист булып эшли иде.* Ф. Кәрим.

МОТОРКА *и. сөйл.* Моторлы көймә. *Искәндәр моторка яллап Ладога күленә килде.* Г. Гобәй. [*Идел өстендә*] *кечкенә моторкалар чабып йөри.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

МОТОРЛАШТЫРУ *ф.* 1. Эш коралларын һ. б. ш. мотор системасына күчерү.

2. *хәрби.* Моторлы машиналар белән тәэмин итү. *Моторлаштырылган дивизия.*

МОТОРЛЫ *с.* Мотор белән хәрәкәткә китерелә торган, йөртелә торган. *Су буенда таллар арасында моторлы көймә гөрелтесе вә суның икенче ягыннан шәһәр шау-шулары йомшак моңланып кына ишетелә иде.* Ш. Камал. || Мотор белән эшли торган. *Моторлы үүкеч.* □ *Яшь егеткә моторлы пычкы белән яки трактордә, автомашинада эшләве әйбәтрәк.* Г. Әпсәләмов.

МОТОЦИКЛ *и.* Эчке янулы двигатель ярдәмендә йөри торган, велосипед формасындагы ике яки өч тәгәрмәчле машина. *Тырылдап, җитез борылышлар ясап, мотоцикллар узып китә.* А. Шамов.

МОТОЦИКЛИСТ *и. к.* мотоциклчы.

МОТОЦИ'КЛЧЫ *и.* Мотоцикл йөртүче. *Мотоциклчылар ярышы.*

МОХБИР *и. иск. кит.* Газета хәбәрчесе.

МОХИТ *и.* Тирә-юнь, әйләнә-тирә; тирәлек. *Тышкы дөнья вә мохит белән бәйләнеше бик аз булган Мәрьямгә елның бер дәвере [көзе] аерым бер күңелсез тәэсир бирә.* Г. Ибраһимов. *Син булмасаң, бар мохитем, бар хәятым миңа ят.* Ә. Ерикәй.

Мохит диңгезе *иск.* — океан. *Сез арысланнарны тудырган аналар, тәрбия кылып үстергән аталар, сезнең җир кырына, мохит диңгезе янына сугышка киткәнегезне күреп, никадәр шатлансалар да, хаклары бардыр.* Ш. Мөхәммәдев.

МОХТАҖ *с.* Яшәү ихтыяҗлары канәгатьләндерелмәгән, ярлы, фәкыйрь. *Мохтаж семья.* | *рәв. мәгъ. Бетсен инде буржуазлар, дөньяга баш булмасын! Бетсен инде! Ярлылар мохтаж, яланғач йөрмәсен!* Ш. Бабич. || *хәб. сүз функ. юн. килеш. соң.* Берәр нәрсәгә ихтыяҗ булу турында. *Кем белә, бәлки аның куллары бернигә яраксыз булып гарипләнгәндер дә, ул кеше ярдәменә мохтаҗдыр?* Г. Бәширов.

МОХТАҖЛЫК *и.* Мохтаҗ булу хәле, ярлылык, фәкыйрьлек. *Бала, этисезлек һәм мохтаҗлык белән исәпләшергә теләмичә, көннән-көн үсә, көннән-көн түгәрәкләнеп, матурая бара иде.* Ф. Хөсни. *Мохтаҗлыкны моңарчы белми яшәгән ана бүген байлыгыннан мәхрүм калган.* Г. Гобәй. || *юн. килеш. соң.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса ихтыяҗ булу хәле. — *Сөләйман иптәш, намуслы культура көчләренә мохтаҗлыгыбыз зур.* К. Тинчурин. *Фронтның алдагы сызыкларында медицина эшчеләренә мохтаҗлык арта барды.* А. Шамов.

МОШЕ'ННИК *и. сөйл.* Ялганчы, алдакчы, намуссыз кеше. — *Мин аның мошенник икәнлеген тиз сизенә башладым.* Ш. Камал. || Кимсетү, сүгү сүзе: карак. — [*Бай абзый*], *Ник монда чәчәкләр үзеп йөрисең, мошенник малай! — дип, колагымны борып, куып җибәрде.* М. Гафури.

МОШЕ'ННИКЛЫК *и. сөйл.* Мошенник булу.

МОҢ *и.* 1. Кайгы, хәсрәт, борчу. *Мостафа абыйның шат йөзенә, дәртләнеп эшләп йөрүенә карап, инде моның дөньяда бер моңы да калмаган икән, дияргә була иде.* Г. Гобәй. *Кычкырма, күке, ай каршымда. Кычкыр сана агач башында, Моңлы гына бала түгел идем, Моңнар төште башыма.* Җыр. || Аһ-зар. *Исәрме җил тугай буйлап, Елармы кыз моңын сөйләп.* Дәрдмәнд. || Сагыш. *Үзгәрде егет, аны хәзер әллә нинди серле моң басты.* М. Җәлил. *Җанны изә торган авыр моң һәм авыр тойгылар белән мин ишек алдына чыктым.* Ф. Әмирхан.

2. Йөрәк хисе, тирән хис. *Бер дустым бар минем, җырчы егет. Җырларында яңгырый саф моңнар.* Ш. Маннур. *Бу яшь егеткә кайдан килгән бу кадәр моң? Гаҗәеп бер тирән моң белән җырлый иде ул.* А. Әхмәт. || Моңсулык. *Ике якта кечкенә генә тәрәзәләрдән тымызык кына кызгылт утлар күренеп, урамга бер төрле моң вә күңелсезлек биреп тора иделәр.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Моңлы, моңсу. *Аның өзелеп чыккан моң тавышыннан Бөтен хәсрәтләрем таратам.* Ф. Бурнаш. *Ах, синең моң йөзләрең, Нур чәчрәтеп, бер көлсәң!* Н. Исәнбәт.

3. Көй; хисләр җыелмасы. *Паровоз тавышы Гафур өчен дөньядагы бөтен музыкалардан, бөтен моңнардан кыйбат.* К. Нәҗми. *Газинур, халык арасында туган һәм халыкның моңын саф килеш саклый белгән җырчылар шикелле, җырын дәвам иттерде.* Г. Әпсәләмов. *Сиздерт, курай, кайнар тойгыларны, Сөйдерт, сөйләп башкорт моңнарын!* Ш. Бабич.

4. *рәв. мәгъ.* Ниндидер эчке сагыш катнаш моңсулык белән. *Аларның кайсы тәмәке тарта, кайсы салмак кына көйгә гармонь уйный, кайсы авыз эченнән генә моң гына итеп көйләп утыра.* М. Гали. *Скрипка тавышы һаман шулай әкрен генә, моң гына яңгырый.* А. Шамов. || Сагышландыра, моңландыра торган бер әкренлек белән. *Ай йөзә моң гына, моң гына.* Җыр. *Яктылык әкрен генә, моң гына сүнде.* Каз. утл.

5. *диал.* Кимчелек, җитешсезлек. *Җирнең моңы юк, җир начар түгел, без үзебез начар.* Г. Бәширов.

МОҢА *а.* „Бу“ алмашлыгының юнәлеш килеше формасы.

Моңа кадәр — *к.* моңарчы.

МОҢАЙТУ *ф.* **1.** Кайгыга салу, хәсрәтләндерү. *— Анасы, юкка кәҗәләнеп йөрмә, хәзер үк үзенә: „Киленем“, — диген дә, дуслашыгыз. Моңайтма киленне.* А. Әхмәт.

2. *з-сыз.* Күңелгә моң (1 мәгъ.), сагыш төшү турында. *Нәрсәдер җанны моңайта, нәрсәдер эч яндыра.* Н. Исәнбәт.

МОҢАЧА *рәв. к.* моңарчы.

МОҢАРЧЫ *рәв.* Бу көнгә кадәр, бу вакытка кадәр. *Моңарчы эш башламыйча торалармы!* Каз. утл. || Бу хәлгә, вакыйгага кадәр.— *Юк, моңарчы алай бер дә начар исеме ишетелгәне юк иде.* Г. Камал.

МОҢАЮ *ф.* **1.** Кайгыру, хәсрәтләнү, борчылу. *Хат алырсың тиздән, мине сагынып, моңаеп утырганда.* Ф. Кәрим. || Сагышлану. *Айлы матур кичтә Моңайма син һич тә.* Ә. Ерикәй. || *рәв. мәгъ.* Моң (1 мәгъ.) белән, сагышланып, сагыш белән. *Газиз --- моңаеп карый, аның чырае торган саен караңгылана барган кебек иде.* Г. Бәширов.

2. Боегу, уйга бату, күңелсезләнү. *Ник син алай гел моңаясың?* Д. Аппакова. *Күрәмсез, бер ятим чынлап моңайган.* М. Гафури. *Лаля башын иеп моңаеп тора.* М. Фәйзи. || Уйланып, хисләргә бирелеп утыру. [*Хафиз:*] *Минем, бәлки, ялгызым гына моңаясым киләдер.* Р. Ишморат. || *рәв. мәгъ.* Боегып, күңелсезләнеп, юксынып, уйга батып. *Өр-яңа күлмәк кигән мари бер читтәрәк моңаеп утыра.* А. Әхмәт. *Төне буе айга карап, Мин утырдым моңаеп.* М. Җәлил.

3. Моңлы итеп көйләү, җырлау. *Баласын җуйган тургайдай, Ник моңаясың болай.* Җыр.

4. *күч. шигъ.* Тын гына утыру, моңлы булып күренү, күңелсез булу (җансыз предметлар һәм табигать турында). *Дулкынланган нәфис карлы кырда әрем сабаклары моңая.* Һ. Такташ. *Табигатьнең саргайган, моңайган чагы иде.* А. Шамов.

МОҢДАШ *и.* Кемнең дә булса кайгысын, хәсрәтен, сагышын уртаклашучы. *Ай — юлчының юлдашы, гашыйкларның моңдашы.* Мәкаль. || Нинди дә булса кайгыны, хәсрәтне, борчуны бергә күрүче, бергә кичерүче кеше турында. [*Гариф*] *бигрәк тә Әхмәдулла белән сердәш вә моңдаш булып китте.* М. Гафури.

МОҢ-ЗАР *җыйд. и.* Моң һәм зар, кайгы-хәсрәт. *Ай елмая, ишетми ул хәзер Үткән авыр чорның моңзарын.* Ф. Кәрим.

МОҢЛАНДЫРУ *ф.* **1.** Күңелгә моң салу, сагышландыру. *Таң алдындагы тавышлар ничектер бер үк вакыт моңландыралар да, шомландыралар да.* А. Шамов. || Боектыру. [*Йортның шундый кыяфәте*] *минем эчемне пошыра, күңелемне каралта, моңландыра, әллә нишләтә иде.* Ф. Әмирхан. || *рәв. мәгъ. Гөлнарым күзен моңландырып арттан карап калды.* Ә. Айдар.

2. Моңлы итү, моңын көчәйтү (җыр, көй, тавышны). *Гүя ки [Газизә] шушы такмакларны тагын да моңландырыбрак җырлап йөри имеш.* Ш. Камал.

МОҢЛАНУ *ф.* **1.** Кайгыру, хәсрәтләнү, борчылу. *Илдар миңа юкка ачулана, Ул аңламый, бәлки, еракта, Безне уйлап, Самат абыем да Моңланадыр шулай кайчакта.* М. Җәлил.— *Ул мескен бичарага карап, күңелем тула да моңланам.* Д. Аппакова.

2. Моңлы итеп җырлау, көйләү. *Су буенда, яр башында яшь егетләр моңлана.* Ф. Бурнаш. *Ул ялгыз булса, көйләренә ерактан кушылып, акрын гына моңлана.* Г. Ибраһимов. || Кошлар сайравы турында. *Сандугачлар торып тирәклектә Тургай белән бергә моңлана.* Ә. Ерикәй. || *рәв. мәгъ.* Моңлы итеп, эчке моң белән. *Ишетсеннәр иде дә, моңланып җырлаучының тавышын танып, хәйран калсыннар иде.* Г. Бәширов.

3. Уйчанлану, моңсулану, уйга бату. *Ул гаҗәеп күзләр әллә ничек иркәләнеп, кадерләнеп моңланалар.* Ф. Әмирхан. || Моңлы булып, моңланган кебек булып күренү (табигать турында). *Төн тыныч, күк балкый иренеп, ай яна, ай моңлана.* Н. Исәнбәт.

МОҢЛАУ *ф. диал.* **1.** Моңлану, уйга бату. *Ятам кайчаклары моңлап, һаваның тынлыгын тыңлап.* Дәрдмәнд.

2. Моңлы итеп көйләү, җырлау.— *Илнең картлары, карчыклары минем көемне моңланалар.* Ф. Әмирхан. || Моңлы булып, моңланган кебек булып күренү (табигать турында). *Төн тыныч, күк балкый иренеп, ай яна, ай моңлана.* Н. Исәнбәт.

МОҢЛЫ *с.* **1.** Кайгылы, хәсрәтле, борчулы. *Инде хәзер кулың сузарсыңмы гыйшкың упкынына Кереп баткан моңлы егеткә?* М. Җәлил. || Сагышлы, уйчан, сагыш тулы. *Аның моңлы һәм яшьле күзләре белән карашы минем күз алдыма килеп йөдәттеләр.* Ф. Әмирхан || *рәв. мәгъ.* Күңелгә моң салып. *Карлыгач моңлы сайрый, матур таң тугач.* Җыр.

2. Тирән хисле. [*Кайчандыр*] *аларның дәртле тавышларын, шат көлүләрен, моңлы җырларын сөенә-сөенә тыңлый идек.* Ә. Еники. *Алар, моңлы көйнең тәэсирен югалтмас өчен, урыннарыннан сүзсез генә тордылар.* А. Шамов. || Тирән хис тулы. *Гомерем минем моңлы бер җыр иде, Үлемем дә яңрар җыр булып.* М. Җәлил. [*Кызлар*], *бакчаны моңлы тавыш белән тутырып, әкрен генә җырлыйлар.* И. Гази || *рәв. мәгъ.* Тирән хис белән, моңлы итеп.— *Кулдагы гармонь да башка вакыттагыдан күп дәрәҗәдә моңлы, дәртле уйнаган кебек тоела.* Ф. Хөсни.

3. Моң сала торган, ямансылата, моңландыра торган (табигать күренешләре турында). *Нурлы ул күк, моңлы ул күк, Ул — шагыйрьнең күңле күк!* Н. Исәнбәт. *Рәсемдәге төсле матур, әкияттәге төсле серле, җырдагы төсле моңлы елга ул Агыйдел.* М. Әмир.

4. *и. мәгъ.* Моңы, кайгысы бар кеше, кайгы-хәсрәтле, зарлы кеше. *Моңлы моңын сөйләгәндә, моңсызның башы авырта.* Мәкаль. *Кайда ярлы, кайда*

зарлы, кайда моңлы күп була — Мин шулар янында булам: алар белән килешеп була. М. Гафури.

МОҢЛЫ-ЗАРЛЫ *с.* Кайгылы-хәсрәтле, сагышлы, сагыш тулы. *Әйтеп бирде бөтен үткәнен: Ничек итеп теге заманнарда Моңлы-зарлы дөнья көткәнен.* Ш. Маннур.

МОҢЛЫК *и.* 1. *к.* моңлылык (1 мәгъ.). *Күңелне ниндидер бер моңлык, сагыш биләп алды.* Каз. утл.

2. Моң сала, моңландыра, ямансулата торган тынычлык. [*Галия*] *агач төбенә утыра, бераз моңлык.* Г. Коләхметов.

3. Моңлы көй, җыр. — *Өлкәннәрнең рөхсәте буенча аның бер моңлык әйтүгә исәбе юк түгел иде.* Г. Ибраһимов.

МОҢЛЫЛЫК *и.* 1. Ямансулык. *Кайсыдыр почмакта әллә нинди моңлылык эчендә һаман бернәрсә елый иде.* Ш. Камал.

2. Моң, сагыш. *Аның бөтен торышына, төсенә, күз карашларына матур моңлылык, тирән уйчанлык чыккан.* А. Шамов.

3. Моң, сагыш тулы булу (җырда, тавышта). *Көйнең моңлылыгы.*

МОҢСУ *с.* 1. Берникадәр моңлы, моңайган, сагышлы. *Күл буенда ускән төнбоектай, Сине сөйгән моңсу яр көтә.* Җыр. || Моң, сагыш чагылып торган; моң катнаш. *Аның --- күзләрендә моңсу бер куаныч балкый иде.* Г. Бәширов. [*Катя*] *эче катып көлә һәм аның моңсу коңгырт күзләре очкынланып китәләр иде.* Г. Әпсәләмов. || *рәв. мәгъ.* Моңланып, ямансулап, моңлы итеп. *Моңсу гына кул болгадың Онытма дигән сыман.* Ф. Кәрим. *Аерылганда миннән, туганыңнан Аерылган күк, моңсу калырсың.* Һ. Такташ.

2. Ямансу, күңелсез. *Күп вакытта ул, ятим, моңсу бүлмәсенә кайтырга теләмичә, кабинетында гына кунып кала торган булды.* Ә. Еники.

МОҢСУЛАНУ *ф.* 1. Ямансулау, моңлану. *Эчем пошса, моңсулансам кайчак, Тукайны мин алам кулыма.* Ш. Маннур. || Моң чагылу, моңлылану, уйчанлану. *Йөзлебикәнең ваемсыз чырае моңсуланды.* Г. Бәширов.

2. Моңлы төскә керү, моңайгандай тынычланып калу (табигать турында). *Инде көн кичләтеп бара, кояшның соңгы нурлары, кызарып, моңсуланып, тәрәзә яңагына төшкән.* Каз. утл.

МОҢСУЛАТУ *ф. к.* моңайту. || Моңсу төскә кертү. *Салават, күзләрен берничә секундка гына моңсулатып, кайгысыннан борчылгандай була.* А. Шамов. || *з-сыз.* Күңелгә моң салу. *Төн караңгы, тын. Моңсулата.*

МОҢСУЛЫК *и.* Күңелсезлек, ямансулык, моңлылык. *Җилнең, кинәт тәрәзәгә бәрелеп, стена буйлап сызгырып үтүе, орчыкның өзлексез бызылдавы өйдәге моңсулыкны арттыра, күңелне әллә нинди ямьсез уйлар белән тутыра.* И. Гази. || Моңсу тынычлык турында. *Тып-тын калган дөньяны талгын һәм рәхәт бер моңсулык баса.* Ш. Маннур.

МОҢЧАН *с.* Еш моңланучан (кеше турында).

МОҢЧЫ *и.* Моң (3 мәгъ.) жырлаучы. *Син кичәге ярлылнең Моңчысы булган курай.* Н. Исәнбәт.

МРАМОР *и.* Нигездә скульптура һәм архитектура эшләрендә кулланыла торган төрле төстәге каты тау токымы; мәрмәр. *Соры төстәге мрамор. Кызгылт мрамор.* || *с. мәгъ.* Мрамордан эшләнгән. *Мрамор баскыч төбендә җиңнәрен сызганып бәрәңге арчучы Орлова аны күрү белән үк эшен ташлады.* К. Нәҗми.

МУАФЫЙК *с.* Туры килгән, яраклы, лаек; кулай. *Ул, [председательлеккә] иң муафыйк кеше дип, Һидиятне тәкъдим итте.* Ш. Камал. [*Студент:*] *Монда мин, бер дә мактамыйча гына әйткәндә, ул (вечерның патшасы дигән) исемгә сездән муафыйк кешене таба алмыйм.* И. Гази. | *хәб. функ. Кызның чыннан да исеме җисеменә муафыйк икән.* Сов. әд.

Муафыйк күрү (табу) — 1) кирәк дип исәпләү, урынлы дип санау, кирәк табу. [*Кәрим*] *„Болар мосафирлар, рамазанда көндез ашап утырган өчен гаепли күрмәгез, зинһар“, — дип язып куюны муафыйк күрә.* Ф. Әмирхан; 2) үзенә кулай, тиң санау. *Аның үзенчә бик муафыйк тапкан кызы да бар иде.* Ш. Камал.

МУАФФӘКЫЯТЬ *и. иск. кит.* Уңыш; өстенлек. *Башка кешеләр аңламый торган телдә зур китаплар укуым бик зур муаффәкыять исәпләнә иде.* М. Гафури. *Ул исә бу имтиханны да муаффәкыять белән үткәрде.* Г. Ибраһимов.

МУЕЛ *и. диал.* Шомырт. *Тугайларда муел куаклары, Бөдрә таллар, кырыгый алмалар, Яулык болгап озатып калган кыздай, яфракларын кагып калалар.* З. Мансур. *Каршыбызда күп муеллар, Муелларга кунган былбыллар.* Җыр.

МУЕН *и.* 1. Кешедә яки коры җирдә яшәүче умырткалы хайваннарда — гәүдә белән баш арасындагы нечкәреп килгән өлеш. — *Тиз генә абзарга кердем дә, кырыкмышымны йөгәнләп алып, муенына --- кечкенә кыңгырау тактым.* М. Гали. [*Хәлимнең*] *кара башы, кояшта янган муены, ярты аркасы су эченнән күренеп барды.* И. Гази.

2. Шешә, кувшин кебек нәрсәләрнең нечкәреп килгән урыны.

3. *күч. сөйл.* Үз иреге булмаган, кемгә дә булса буйсынып яши торган кеше турында. *Сафи — муен, Фатыйма апай — баш иде.* Г. Тукай. *Беребез баш, беребез муен түгел, Юлдашлар без якты зур юлда.* З. Мансур.

4. Чалгының сапка божралап беркетелгән урыны. *Ул чормадан чалгыны алып карады да, төзәттерәсе җирләре бар, муены бик йомшак, яңа божра кирәк булыр дип, тимерлеккә китмәк булды.* Г. Ибраһимов.

5. *геогр.* Диңгез яки океан эчендәге коры җир кисәкләрен тоташтырган тар җир полосасы.

6. *чыг. килеш. форм. рәв. мәгъ.* **муеннан.** Муенга кадәр, бөтен гәүдә белән диярлек. *Безнең чишмәләрнең суы чыпчыкка — муеннан, каргага — тездән, — дип кычкырдылар залдан.* Г. Әпсәләмов. — *Шушы салкында муеннан суга чумды бит ул!* Ш. Камал. || *күч.* Бик күп (эш, бурыч, азык һ. б. турында). *Нәфисәнең эше муеннан иде.* Г. Бәширов. *Кукуруз мул булсын, хайваннарга азык муеннан булсын.* Э. Касыймов.

◇ **Муен белән күтәрү** — нәрсә өчен дә булса җавап бирү. *Кулы белән кылганын муены белән күтәрер.* Мәкаль. **Муен тамыры бүртү (кабару)** — ачулану, ачуы чыгу, кызып китү. **Муенга алу** — (гаепне) үз өстенә алу, гаебен тану. [*Исмәгыйль:*] *Мин бу эшне эшләвемә үкенеп, гаебемне муеныма алам.* М. Фәйзи. **Муенга асылыну (асылу, сарылу)** — 1) кемнедә булса иркәләп, яратып муеныннан кочаклау. *Кич кайтып яткач, Нәҗия аның муенына сарылып гөрләргә тотына.* Ә. Еники; 2) кемне дә булса яраттырырга тырышу, ялыну, артыннан йөрү. *Хатын-кыз бервакытта да синең муеныңа килеп асылынмас.* Сов. әд; 3) йөк булып тагылу, калмау, йөдәтү. **Муенга бау (җеп, әлмәк) салу** — асылыну, асылынып үлү. — *Агу эчәләр, имеш, теге хатын да шуның ачуыннан үз муенына җеп салган, имеш.* Ш. Камал. **Муенга камыт кию** — ниндидер җаваплылыкны өстенә алу турында. [*Мирзаян:*] *Авыл хуҗалыгы институтын бетергәч, муенга камыт кигәнче, дигәндәй, шулай бер үзебезнең туган яклардан урап*

кайтырга булдым. Ф. Хөсни;— *Яшьлекне дә бераз күрергә кирәк, өйләнгәч, муенга камыт киелә, дөнья баса башлый.* Г. Әпсәләмов. **Муенга (менеп) атлану**— 1) кемнең дә булса исәбенә яшәү; 2) кем өстеннән булса да өстенлек итү. [*Биктимер:*] *Мироныч та китсә.* [*Мирзаханнар*] *муенга менеп атланырлар инде.* Т. Гыйззәт. **Муенга тагылган таш** — мәшәкать тудыручы, җан көеге. **Муенга тагылу** — 1) *к.* муенга менеп атлану. [*Нурия:*] *Быел да шулай өчәүләп минем муенга тагылмакчы буласызмы әллә?* К. Нәҗми; 2) кемгә дә булса авыр йөк булу. **Муеннан ашу** — бик күп булу, кирәгеннән артып китү.— *Җитте, муеннан ашты бу! Шушы юньсез нәрсә күпме кешеләрнең башына җитте бит!* Сов. әд. **Муенны кисү**— максатка, теләккә ирешүдә берәр төрле комачау яки җитмәүчелек турында. [*Бикмулла:*] *Минем дәрман җитенкерәми, оланнар. Ат кисә муенны, ат!* Г. Бәширов. **Муены сынсын (сынгыры), муены астына килсен (килгере)** — сүгү, ачулану, каргау сүзе: дөмексен.— *Минем чебешемә тигән өчен аның муены астына килсен.* А. Алиш. **Муены сыну** — теләгенә, максатына ирешә алмау, уңышсызлыкка очрау, юкка чыгу, һәлак булу.— *Кайгырмагыз, озакка түгел бу аерылу. Тиздән муены сыначак бу канечкечнең.* К. Нәҗми. **Муенын бору** — 1) бетерү, үтерү. *Шул арада атам бер чебешнең муенын борып, коега бәрде.* З. Һади; 2) җәза бирү, шелтәләү.

МУЕНСА *и.* 1. Таштан, гәрәбәдән, пыяладан һ. б. материалдан ясалган төрле формадагы һәм төрле зурлыктагы төймәләрне җепкә тезеп, муенга тагу өчен ясалган бизәү әйбере. *Күкрәгендә менә шундый ук әнҗе, муенса бар иде.* Ф. Бурнаш. *Кунак хатын, тынгысызланып, бер залга, бер Айсылу белән Тимергә карап алды, муенсасына кагылып куйды да урыныннан торды.* Г. Бәширов.

2. *к.* муенчак. [*Әйдүк*] *Караборынның муенындагы муенсасын алды да муенса эченә төрелгән берничә кәгазь чыгарды.* Һ. Такташ.

МУЕНСЫЗ *с. сөйл.* Характерсыз, йомшак характерлы, принципсыз.

МУЕНСЫЗЛАНУ *ф. сөйл.* Йомшак характерлы булу, принципсызлык күрсәтү. *Закир болай әйбәт егет үзе, ләкин кайбер вакыт бик беркатлылана, анасы сүзенә ятып, муенсызланып та куйгалый.* Г. Ибраһимов.

МУЕНЧАК *и.* 1. Хайван муенына кидерү яки бәйләү өчен махсус эшләнгән каеш яки юкә бау. *Муен булса, муенчак табыла.* Мәкаль. [*Бозаулар*] *муенчакларын тартып, башларын аска иеп мөгриләр.* А. Шамов. *Илсөяр, этнең шикләнгәнен аңлап, муенчагыннан тотып, сөя-сөя тышка алып чыкты.* Г. Гобәй.

2. Дар бавы. *Сатлык җаннарның язмышы һәркайчан я муенчак, я пуля астында тәмамлана.* Каз. утл.

◇ **Муенчак кию** — ниндидер җаваплылыкны өстенә алып иректән мәхрүм булу. [*Бибиҗамал апа:*] *Шушы яшеннән өйләнеп, муенына муенчак киюнең ни кызыгы бар инде?* Ш. Хөсәенов. **Муенчак салу** — 1) асу.— *Ябу гына түгел, синең кебекләргә муенчак салырга да кыйбат алмыйбыз.* Т. Гыйззәт; 2) ирексезләү, көчләү, куркытып мәҗбүр итү.— *Мондый шартларда аларны муенчак салып та эшләтеп булмас.* Б. Камалов; 3) тыю, теләкләренә комачаулау. *Җитәр инде, бик күп чыдадым,— ди. Бик күп түздем синең көлкеңә. Минем яшисем килә теләгәнчә, Муенчак салма минем иркемә.* Ш. Маннур.

МУЕНЧАКЛАУ *ф.* 1. Муенчак бәйләү, кидерү. *Билемдәге каешны чишеп алып, аның белән бүрене муенчакладым.* Г. Галиев. || *рәв. мәгъ.* **муенчаклап.** Муенчак белән. *Почмакта муенчаклап бәйләнгән яшь бозау белән ике сарык бәрәне дә бар.* М. Гали.

2. *күч. к.* муенчак салу (1, 2 мәгъ.).— *Аны киткән җиреннән муенчаклап кына кайтарып булыр!* Ф. Бурнаш.

МУЖИК *и. сөйл.* Крестьян.— *Бу мужикның әллә тавыклары бөтенләй юк инде?* К. Тинчурин. | *с. мәгъ.* [*Зөләйха абыстай:*] *Киләләр дә аның Зыясын башка мужик егетләре рәтеннән никрут ясамакчы* [*булалар*]. Г. Ибраһимов.

МУ'ЗА *и.* 1. Грек мифологиясендә: фән һәм сәнгатьне яклаучы тугыз алиһәнең берсе.

2. *күч.* Иҗат дәрте, иҗат көче, илһам бирүче. || Шагыйрь иҗаты, поэзия, җыр. *Син көрәштә батыр булдың, Муса, Җырың белән җиңеп үлемне. Канатында алып кайтты муза Туган илгә синең гомерне.* Н. Дәүли.

МУЗЕЙ *и.* Сәнгать әсәрләрен, техник, тарихи, фәнни-табигый экспонатларны һ. б. җыеп саклый һәм күргәзмәгә куеп тота торган учреждение. *Госпиталь каршысында гына тарих музее бар.* Г. Гобәй. [*Хәмит:*] *Мин инде электән үк музейда алтын акчалар һәм бизәнү әйберләре барлыгын белә идем.* А. Расих.

МУЗЕЙЧЫ *и.* Музейда эшләүче белгеч.

МУ'ЗЫКА *и.* 1. Чынбарлыкны көйле художество образлары аша тасвирлый торган сәнгать төре. *Музыка белеме. Музыка факультеты.* □ *Зыя музыка сөя, хәтта өендә музыка коралында уйнарлык батырлыкка да барып җитә.* Г. Нигъмәти. || Шундый төр сәнгать әсәре яки әсәрләр җыелмасы. [*Гөлзадә:*] *Музыканы шәһәр генә язарга дигән закон юк ла бездә.* Р. Ишморат. *Фатыйма рояль янына утырып ноталар сайлады: залда „Фауст" музыкасыннан бер кисәк яңгырады.* Ф. Әмирхан.

2. Шундый сәнгатьнең, җырлау-вокаль төреннән аермалы буларак, инструментта башкарылган төре. *Җырчылар музыка һәм вокаль буенча махсус дәреслеләрне аерым педагогларның классларында үттеләр.* М. Җәлил.

3. *күч.* Нәрсәнең дә булса колакка ятышлы булуы, авазларның аһәңлелеге, гармониялелеге. *Сөйләм музыкасы.* □ [*Алар*] *бүрәнәләргә „чәп-чәп" бәреп торган су музыкасы астында изелеп йоклап китәләр.* М. Гали.

4. *сөйл.* Оркестр. *Музыка интернационал уйнаганнан соң, институт бетереп чыгучыларны тәбрикләүләр булды.* Каз. утл.

5. Гомумән җыр, көй. *„Көт, иркәм" дигән гүзәл сүзең Музыка төсле тоела миңа.* Ә. Ерикәй.

МУ'ЗЫКАЛАШТЫРУ *ф.* 1. Музыкага салу. *Поэманы музыкалаштыру.*

2. Музыка (5 мәгъ.) катнаштыру, музыка кертү. *Драма әсәрләрен музыкалаштыру.*

МУ'ЗЫКАЛЫ *с.* 1. Көйле, җырлы; көйгә, җырга салынган.

2. *к.* музыкаль (3 мәгъ.). *Хәерниса әлекке матур, уенчак, җиңел музыкалы тавышын да югалтты, әлекке шаян сөю җырлары аның теленә, ничектер, килми башладылар.* Г. Ибраһимов.

Музыкалы сәгать — суккан вакытта музыка уйный торган сәгать. *Бу вакытта шәһәрнең музыкалы сәгате үзенең мәхәббәтле тавышы белән сәгать дүрт* [*тулганын белдерде*]. Ф. Әмирхан.

МУЗЫКАЛЬ *с.* 1. Музыкага мөнәсәбәтле. *Хор башлыча Казандагы төрле музыкаль предприятиеләр кадрларыннан төзелде.* М. Җәлил.

2. Музыка чаралары белән белдерелә торган. *Музыкаль образлар.*

3. Колакка ятышлы, матур яңгырашлы. *Бу музыкаль, ягымлы тавышны күземне йомган килеш кенә тыңларга минем көчем житми.* Ә. Айдар.

4. Музыка белән башкарыла, алып барыла торган. [*Бу әсәрне*] *„комедия“ дип атаудан бигрәк „музыкаль пьеса“ дип атау яхшырак булыр төсле.* М. Гали.

МУЗЫКАЛЬЛЕК *и.* Музыкаль булу (сыйфаты). *Һ. Такташ шигырьдә сюжетлылык, драматизм, музыкальлек мәсьәләләрен иҗади хәл итте.* Х. Хәйри.

МУЗЫКАНТ *и.* **1.** Музыка белгече. *Бу яшь буын эченнән яңа илнең политик житәкчеләре, --- язучылары һәм шагыйрьләре, музыкантлары һәм югары квалификацияле яшь эшчеләре күтәрелеп чыкты.* Г. Бәширов.

2. Музыка коралында уйнау белән шөгыльләнүче кеше. *Аңа берәү дә яшьтән системалы белем алып --- музыкант булырга юл күрсәтмәде.* М. Җәлил.

МУ'ЗЫКАЧЫ *и.* Музыкант.— *Сәйдәшев дигән яшь музыкачы үзен дирижёрлыгы белән таныгты.* Тат. театры.

МУКШЫ *и.* Мордва халкындагы ике этник группаның берсе. *Мукшының уңган килене аяк өсте ашый.* Мәкаль. [*Килүчеләр*] *арасында рус та, татар да, чуваш та, мукшы да, мари да, ар да бар иде.* М. Гали.

МУЛ *с.* **1.** Бик күп, шактый күп. *„Красногвардеец“-тан нибары бер чакрымда мул сулы көчле елга ага иде.* Г. Әпсәләмов. *Егетләргә премия рәвешендә мул гына акча да әләкте.* Г. Ахунов. || *рәв. мәгъ.* Күп, житәрлек, теләгән кадәр. *Чәйнең мул торганы яхшы, чәй бетеп китсә, уңайсыз була ул.* Ф. Әмирхан.

2. Бай. *Нинди мул ел булгандыр ул, белмим — җәнлекләр, кош-кортлар шулкадәр күп иде.* А. Шамов. [*Балалар*] *мәктәп китапханәсендә иген үстерүгә карата нинди китап, журнал бар, алып кайтып, мул уңышка ирешүнең серен эзләделәр.* Г. Гобәй. | *рәв. мәгъ. Быел җәй искиткеч мул килде.* Каз. утл.

3. *сөйл.* Иркен, зур, киң (күләмле). *Чалбарың бик мул.*

◇ **Мулдан булу** (исәп, өмет турында) — күпне көтү, күпне өмет итү. [*Сәйфи:*] *Ай-яй! Мулдан икән үзеңнең исәп.* Г. Бәширов. **Мулдан кылану (ычкындыру, кубару)** — 1) үзенең бай, хәлле булуын күрсәтергә тырышу; 2) күпләп тарату, тоту, юкка әрәмшәрәм итү.— *Ул бик мулдан ычкындыра.* Г. Камал. **Мулы белән** — артыгы белән.— *Бишмәтнең эчлегенә күпме кирәк булыр икән?— Биш метр мулы белән житәр.* М. Гафури.

МУЛАТ *и.* Негр белән ак тәнле кешеләр никахыннан туган буын, нәсел.

МУЛАЮ *ф.* Мул булу, күбәю, арту. *Дәрәҗә зураю сәбәпле керәчәк хосуллар да мулая башлаган иде.* Г. Ибраһимов. || Зураю, үзенә зур булып калу (кием турында).

МУЛИНЕ *и.* Төсле чигү жебенең бер төре. *Ул итәгенә мулине җепләрен җыеп утырган да чигү чигә.* Каз. утл.

МУЛЛА *и.* **1.** Мөселманнарда дин әһеле; мәхәлләдә дин башлыгы. *Югары мәхәллә мулласы Сөләйман хәзрәт никах укыды.* Г. Ахунов. *Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала?* Мәкаль.

2. *иск. сөйл.* Кешегә ихтирам белән, олылап мөрәҗәгать итү сүзе, исем алдыннан әйтелә.— *Чү, мулла дхмәтҗан, алай каты әйтмә.* Г. Камал. || *күч. иск.* Укымышлы, галим кеше. *Укып мулла булмассың, чукып карга булмассың.* Мәкаль.

Мулла кем *иск. сөйл.*— *к.* мулла (2 мәгъ.).—*Кара әле, мулла кем, мөхәррир әфәнде, мин сиңа бер сүз дә әйтмим.* Х. Кәрим.

МУЛЛАБИКӘ *и.* Мулла хатыны. *Муллабикә абыстай бу колларча буйсынучан хатынны аш өендә генә эшләргә калдырды.* Г. Минский.

МУЛЛАЛЫК *и.* Мулла булу дәрәҗәсе, мулла вазифасы. [*Шәкерткә*] *муллалыкка урын юклыклар, өйләнергә акча юклыклар күренә башлый.* Ф. Әмирхан. [*Минем әтием*] *муллалыкка укып чыгып та мулла булырга теләмәгәне өчен бабай тарафыннан каргалган кеше була.* Каз. утл.

◇ **Муллалык итү** — мулла булып тору, мулла вазифасын үтәү.

МУЛЛАНУ *ф.* Күбәю, мул булып китү.

МУЛЛА-МУНТАГАЙ *җыйм. и. кимс.* Муллалар һәм шулар кебек һәртөрле дин әһелләре. [*Гөлгенә әби:*] *Мулла-мунтагай бик мут ул, яңгыр боткасы дигән булып, байтак нәрсә җыеп алды, барыбер яңгыры яумады.* Х. Садрый.

МУЛЛЫК *и.* Байлык, барлык. *Без чик куеп җирдә коллыкка, Җирне күмеп чиксез муллыкка, Бизәрбез барлык илләрне Бергәләшеп гөлләргә.* Ә. Исхак. *Язгы яңгыр — көзге муллык.* Мәкаль.

МУЛЬТИПЛИКАЦИОН *с.* Мультипликациягә мөнәсәбәтле. || Мультипликация юлы белән эшләнгән. *Балалар өчен мультипликацион фильм.*

МУЛЬТИПЛИКА'ЦИЯ *и. махс.* Хәрәкәтнең эзлекле фазаларын сурәтли торган аерым рәсемнәрне яки күләмле фигураларны плёнкага төшерү (шуны экранда күрсәткәндә хәрәкәтләнми торган объектлар хәрәкәтләнгән булып күренә). || Шундый максатлар өчен файдаланыла торган рәсемнәр һәм фигуралар.

МУЛЬЧА *и. а.-х.* Мульчирлау өчен файдаланыла торган материал. *Химик әлпә бик яхшы мульча булып тора. Аның астында гажәеп яхшы дым һәм температура шартлары барлыкка килә.* Соц. Тат.

МУЛЬЧИРЛАУ *ф. а.-х.* Туфрак өстен җылылык һәм дым саклау өчен кәгазь, толь, торф, салам һ. б. ш. нәрсә белән каплау. *Чәчүлекне мульчирлау.*

МУМ *и. иск.* Балавыз. || Шәм.

МУМЛАУ *ф. иск.* Балавызлау. *Таһир өчен эшләнгән сандыкны, Зөһрәнең кушуы буенча, су үтмәсен дип, бик нык мумлап әзерлиләр.* Х. Хисмәтуллин.

МУ'МИЯ I *и.* **1.** Бәлзәмләү аркасында черемичә саклана торган мәет. *Мисыр мумияләрен муслинга төрә торган булганнар.* Каз. утл. || Һава һәм туфракның табигый шартларында кипкән, ләкин черемәгән мәет.

2. *кимс.* Ябыклыгы, хәрәкәтчән һәм тормышчан булмавы белән кипкән мәеткә охшаган кеше турында: тере мәет.

3. *бот.* Май аенда тут агачының ботакларына ябыша торган кабарынкы, кипкән корткычлар.

МУ'МИЯ II *и.* Майланып һәм специфик ис аңкытып тора торган ачык кызыл һәм кызгылт-көрән төслөрдәге балавызга охшаш минераль буяу. *Мумия тәмгә ачы, суда, бензинда, спиртта тиз эри.* Соц. Тат.

МУНДИР *и.* Хәрби яки тимер юл, элемтә һ. б. ш. эшләрдә киелә торган махсус кием. *Җамали [солдат], иртән сәгать алтыдан торып, үзенең мундирларын чистартты.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Мундирга мөнәсәбәтле. *Мундир төймәләре.*

МУНДИРЛЫ *с.* Мундир кигән. *Мундирлы кеше.*

МУНИЦИПАЛИЗА'ЦИЯ *и.* Кемнең дә булса шәхси милкен (мәсәлән, җирен, корылмаларын) дәүләт тарафыннан урындагы идарә органнарына тапшыру.

МУНИЦИПАЛИТЕТ *и.* Буржуаз илләрдә җирле үзидарә органы һәм шуның бинасы.

МУНИЦИПАЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Муниципализация үткәрү.

МУНЧА *и.* Парланып, чабынып юына торган махсус бина. *Ак мунча. Кара мунча. Җәмәгать мунчасы.* □ *— Яксам — мунчам, чыксам — бакчам бар дигәндәй, нинди кайгым булсын соң минем?* А. Әхмәт. *Төтен кара мунча төнлегеннән чыккандай куе булып, бөркелеп чыга.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Мунчага, юынуга мөнәсәбәтле. *Мунча сабыны. Мунча себеркесе.*

◇ **Мунча кебек** — 1) бик әссе (бүлмә турында); 2) кечкенә. — *Аларның бит мунча кебек җир өйләреннән башка бер нәрсәләре дә юк.* Г. Гали. **Мунча кертү** — каты шелтәләү, сүгү, ачулану, тәнкыйтьләү. *Өч көннән соң минем диндар әти Мунча кертте шомырт таяклап.* Ш. Маннур. **Мунча керү** — каты шелтә алу, тәнкыйтьләнү. *Минем бер дә синең аркада райком бюросында мунча керәсем килми.* А. Расих. **Мунча тараканы** — кешене кимсетеп әйтелә. *Һе! Әвен әүлиясы, мунча тараканы!* Ш. Камал. **Мунча ташы (кебек)** — бик хәйләкәр, зирәк һәм усал кешегә карата әйтелә. **Мунча фәрештәсе (пәрие)** — бик әшәке, кыяфәтсез, сөйкемсез мәгънәсендә (хатын-кызны кимсетү сүзе). [*Зөлсәгыйдә:*] *Алла, алла, бәбәгемне чыгардың. Менә сиңа, менә, мунча пәрие.* Т. Гыйззәт.

МУНЧАК *и. сөйл. к.* муенчак (1 мәгъ.). *Бер үгезгә бер юкә мунчак җитәр.* Мәкаль.

МУНЧАЛА *и.* 1. Юкә кайрысын суда озак җебетеп алына торган киң җепселләр (чыпта хәзерләүгә, бау ишүгә һ. б. китә). — *Ә син беләсеңме, дус, мунчала сала торган күлне?* Ә. Фәйзи. — *Юкәне батырсаң, ичмасам, аңардан менә дигән мунчала чыга.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Мунчаладан ясалган. *Мунчала бавын бер атна элек ишеп куйдык.* К. Нәҗми.

2. Юыну яки савыт-саба юу өчен хәзерләнгән бер тотам мунчала яки мунчалага охшаган, мунчала сыман нинди дә булса башка нәрсә (мәс., диңгез үләне, кәгазь һ. б.). *Мәймунә түти килеп мунчаның кайдалыгын күрсәтте һәм мунчала, сабыннарының кайда торганлыкларын әйтте.* М. Гали.

◇ **(Аякка) мунчала булып уралу** — кемгә яки нәрсәгә дә булса комачаулау. [*Булат меньшевиклар турында:*] *Болар партиянең аягына мунчала булып уралалар, пролетариатның көрәшенә комачаулыйлар.* Г. Ибраһимов. **Мунчала кебек булу** — тузып бетү. *Аның портфеле мунчала кебек булып беткән.* А. Әхмәт. **Мунчала кашыгы ясау** — ара бозу, бутау, болгату. — [*Ул, Газизә турында*] *киявгә әләкләп, өйне мунчала кашыгы ясап бетергән иде.* Ш. Камал. **Мунчала төшерү (сую, каезлау)** — юкә кайрысының җепселле катлавын аеру, аерып алу.

МУНЧАЛАЛАНУ *ф.* 1. Юкә кайрысында мунчала (1 мәгъ.) хасил булу.

2. *сөйл.* Мунчалага (2 мәгъ.) әйләнү, тузып бетү. || *күч.* Нәрсәнең дә булса тәртипсез хәлгә килүе турында.

МУНЧАЛАЛАУ *ф.* Мунчалага (2 мәгъ.) әйләндерү, мунчала кебек итү.

МУНЧАЛАЛЫК *и.* Мунчала чыгару өчен хәзерләнгән юкә кайрысы. *Алар себеркеләр бәйлиләр, бастырмалыклар юналар, елгага мунчалалыклар саналар.* Г. Галиев.

МУНЧАЧЫ *и.* Мунчада эшләүче. *Сафуан агай ул тормышта сирәк очрый торган кызык бер мунчачы иде.* Сов. әд.

МУР *и. гади с.* Үләт, эпидемия. *Чума муры.*

◇ **Мур кыргыры** — каргау, сүгү сүзе. *Ул, мә сиңа, мур кыргыры, мә, мә! дип, песинең кай җире кычытса, шул җиренә бәреп, ыргытып җибәрде.* Һ. Такташ. **Мур кыру** — эпидемиядән күпләп үлү, һәлак булу турында. — *Ай-вай лабаса, игеннәрне боз сугып, ач калмагаек, терлек-туарны мур кырмагае.* Г. Бәширов.

МУРДА *и.* Тал чыбыгыннан яки камыштан үреп эшләнгән балык авы, сөкә. *Менә бер көн балыкчы бу чокырга, Балыкларга китереп салды мурда.* М. Гафури.

МУРДАЛЫК *и.* Мурда үрергә яраклы тал-чыбык. || *с. мәгъ.* Мурда үрергә яраклы. *Мурдалык тал кисеп алып кайттык.* Сов. әд.

МУРТ *с.* 1. Гомумән агач турында: йомшак, көпшәк. *Зирек утын мурт була.* Мәкаль.

2. Искергән, иске. *Мурт тире.*

Мурт тал — талның тиз сынучан төре. *Умартачылык өчен талларның түбәндәге төрләләре әһәмиятле: кәҗә талы, мурт тал, бөдрә тал, кара тал һ. б. таллар.* Умартачылык.

МУРТАЮ *ф.* Искерү, черү, череп ваклану, уалу хәленә килү (агач, тире һ. б. турында). *Муртайган такта койма.* □ *Муртайган бүрәнә ярыкларыннан, сыланмаган тәрәзәләрдән будка эченә җил өрә.* Г. Гобәй.

МУСКАТ *и.* 1. Ябык орлыклылар семьялыгыннан мәңге яшел тропик Азия агачы һәм аның парфюмериядә, медицинада, аш-су пешергәндә файдаланыла торган тәмле исле орлыгы, чикләвеге.

2. Виноградның хуш исле сорты һәм шул виноградтан алынган йөзем җимеше. *Ак мускат. Алсу мускат.*

3. Шул сорт йөзем җимешеннән ясалган яхшы сыйфатлы кызыл аракы. *Беренче класс салонында шәфәкъ кебек алсу мускат та* [*бар иде*]. Ф. Хөсни.

МУ'СКУЛ *и.* Кешеләрдә һәм хайваннарда кыскару үзлеге булган итләч тукыма. *Йөрәк мускуллары. Күл мускуллары.* □ [*Кәримнең*] *җилкәсе киң, белгендәге мускуллар кабарып торалар.* А. Әхмәт. *Аның мускуллары да калынайган, беләкләре дә юанайган.* М. Гали.

МУСКУЛАТУ'РА *җый. и.* Мускуллар. *Очлыклар мускулатурасы.*

МУ'СКУС *и.* Кабарга һәм кайбер башка ата хайваннарның бизләреннән алына торган исле матдә (парфюмериядә һәм медицинада файдаланыла). || *иск.* Составында шундый матдә катнаштырылган хушбуй.

МУСЛИН *и. махс.* Бик юка, җиңел, йомшак тукыма. *Ефәк муслин. Йон муслин.* □ *Тарихи документлар күрсәткәнчә, дүрт-биш мең ел элек үк Мисыр мумияләрен Һиндстаннан китергән муслингә төрә торган булганнар.* Каз. утл. [*Ысланган әйберләрне*] *муслин кебек тукымадан тегелгән капчыкларга салып чардакларга элеп куйсаң, алар тагын да яхшырак сакланалар.* Йорт эшләре. || *с. мәгъ.* Муслиннан тегелгән, муслиннан ясалган (эшләнгән). *Муслин күлмәк. Муслин пәрдә. Муслин шарф.*

МУСС *и.* Җиләк-җимеш суына желатин яки манный ярмасы кушып хәзерләнгән тәмле, баллы ашамлык. *Алма муссы. Мүк җиләге муссы.*

МУССОН *и. геогр.* Вакыт-вакыт үзенең юнәлешен үзгәртеп, җәен диңгездән, кышын коры җирдән исә торган җил. *Җәйге муссон җиле.* □ *Океаннан искән көчле муссоннар илгә мул явым-төшем китерә.* Каз. утл.

МУСТАНГ *и.* Кыргыйланган йорт аты (Төньяк Америкада очраштыргалаган).

МУТ *с. сөйл.* 1. Үткен, зирәк; хәйләкәр. *Егет булса, мут булсын, ике күзе ут булсын.* Әйтем. [*Әбелхарис:*] *Чыккан чакта бер тартыгыз Шул чыбылдык бавыннан Һәм мәңгегә котылырсыз Ул мут егет авыннан.* Н. Исәнбәт. *Алдакчы гына түгел, бик мут та була Якуп мәрхүм.* Г. Гобәй. | *рәв. мәгъ.*

[*Ул Шәрифуллага*] *карап, мут кына көлеп җибәрде.* А. Шамов.

2. Шаян, шук, азгын. *Мут кыз.* □ *Нажияне эшкә урнаштырырга Мостафинның күңеле тартмый иде: һәр җирдә мут ирләр була, Нажия хискә тиз бирелүчән.* Ә. Еники. || Азгынлык. *Агачның корысын корт ашый, кешенең олысын мут ашый.* Мәкаль.

МУТЛАНУ *ф.* **1.** *сөйл.* Хәйләкәрләнү.— *Кайчагында артель башлыгы аз-маз гына мутлана икән, шуның өчен дә башлык ул.* Ф. Хөсни.

2. Шаянлану, шаяру, шуклану, кылану.— *Әйдә, әйдә, мутланма әле, күзләреңне дә май ашаган мәче кебек ялтыратма,— диде Миңнурый.* Г. Әпсәләмов. *—Кайгырма, Гайшә, мутлана башласа, мин бик тиз аның колагын борырмын.* Ф. Бурнаш. || *рәв. мәгъ.* Шаярып; кыланып, кыланчыкланып. *Әпипә, мутланып, тамак төбе белән генә тагы көлде.* Г. Бәширов.

МУТЛЫК *и.* Хәйләкәрлек, шуклык, шаянлык; усаллык, азгынлык. *Шакирның тел төбендә нинди дер мутлык яшерелгәнлеген сизенеп, Рифгать сагая калды.* М. Әмир.— *Безнең кәҗәнең кайчан абзарда кунганы бар? Төне буе мутлыкта йөреп, туеп кайта да өйалдына кереп саудыра.* С. Рафиков.

МУТОН *и.* Сарык тиресеннән махсус эшкәртелгән мех. [*Мәрьям*] *кунакка барганда гына кия торган мутон якалы өр-яңа пальтосын киде.* А. Расих.

МУ'ФТА *и.* **1.** Кулларны җылыту өчен гадәттә мехтан кечкенә капчык сыман итеп, ике башы ачык калдырып тегелгән әйбер.

2. *тех.* Бакларны, трубаларны һ. б. аеру яки тоташтыру өчен хезмәт итә торган җайланма. *Агач муфта.* □ *Бораулау вакытында трубалар өзелә, тоташтыру муфталары ярыла.* Нефть турында хикәяләр. [*Садыйков*] *скважина янына килде дә муфтадан нәкъ урталай өзелгән свечага карап аптырап калды.* Р. Ильяс.

МУ'ШКА *и.* Аткан вакытта туры төзәү өчен мылтык, винтовка һ. б. көпшәсендә махсус чыгынты. *Без бик яшьли Корыч мушка аша Дошман күзәтергә остардык.* М. Җәлил.— *Чак кына югарырак кирәк, --- мушканың башы алмага тиеп торсын.* Ш. Камал.

◇ **Мушкага алу (утырту)** *сөйл.* — кемгә яки нәрсәгә дә булса төзәү. *Миңнулла [дошманны] кабаланмыйча гына мушкага утыртты.* Г. Әпсәләмов.

МУШКЕТ *и. тар.* Эре калибрлы борынгы ату коралы (мылтык төре).

МУШКЕТЁР *и.* Мушкет белән коралланган солдат. || *с. мәгъ.* Мушкетёрга мөнәсәбәтле. *Мушкетер мундиры.* || *с. мәгъ. күпл.* Мушкетерлардан торган. *Мушкетерлар полкы.*

МУШТРА *и.* Механик дисциплинага һәм төшенмичә ятлау алымнарына нигезләнгән хәрби өйрәтү методы һәм шундый юл белән өйрәнү эше. *Ул патша армиясенең авыр муштра мәктәбен үткән.* Каз. утл. || Механик дисциплинага нигезләнгән тәрбия методы.

МЫГЫРДАВЫК *и. к.* мыгырдык.

МЫГЫРДАНУ *ф. к.* мыгырдау. *Ул, һавага бер күтәрелеп, бер төшеп сайрый торган сабан тургена карап, авыз эченнән үз-үзенә әллә нәрсә мыгырдана.* М. Гали.

МЫГЫРДАУ *ф.* **1.** Аңлаешсыз һәм ишетелер-ишетелмәс итеп үзалдына нәрсәдер сөйләнү. *Борисов, ирен читен елмайган сыман кыймылдатып, нидер мыгырдады, күзен ачмыйча гына кулын сузды.* Г. Бәширов. *Сафа тик кайчак кына, борын астыннан мыгырдап, үзенең ни өчен чеметкәнен әйтә.* А. Шамов.

2. Сукрану, нәрсәдән дә булса ризасызлык, канәгатьсезлек белдерү. [*Миңнулла*] *аты яныннан тырыктырык йөгерә, теш аралаш сүгенә, мыгырдый.* И. Гази. *Ул, әзләдем, әзләдем, таба алмадым, дип мыгырдарга керешкән.* Д. Аппакова.

МЫГЫРДАУЛЫ *с.* Мыгырдауга охшаган. *Аның мыгырдаулы тавышы һәм гөман дигән сүзе ни өчендер Габдуллага ошамады.* Ә. Фәйзи.

МЫГЫРДЫК *и.* **1.** Борын астыннан гына аңлаешсыз итеп, мыгырдап сөйләүчән кеше.

2. Сукранучан, сукранырга яратучан кеше, мыжгылдык.

МЫГЫР-МЫГЫР *аваз изр.* Берөзлексез, әкрен генә, ишетелер-ишетелмәс яки аңлаешсыз итеп сөйләнгән вакытта яисә нәрсәдән дә булса ризасызлык белдереп сукранганда була торган авазлар җыелмасын белдерә. *Дошманның мыгыр-мыгыр сөйләшүләре ап-ачык булып ишетелә.* Г. Әпсәләмов.

МЫДЫРДАУ *ф.* Берөзлексез сөйләү турында. [*Телефонист егет:*] *Шушында, өстәл артында, мыдырдап утырырга беттеме икәнни берәр кыз.* Ф. Кәрим.

МЫДЫР-МЫДЫР *аваз изр.* Әкрен генә һәм аңлаешсыз итеп берөзлексез сөйләшкәндә була торган авазлар җыелмасын белдерә. *Чулпан халкы, үзара мыдыр-мыдыр сөйләшеп, авыл уртасындагы клуб бинасына бара.* Г. Бәширов.

МЫЕК *и.* **1.** Ирләрдә — өске ирен өстендәге төкләр. *Студент садә генә, ләкин килешле киенгән, ябык кына битле, коңгырт чәчле, яңа гына мыек чыга башлаган егет иде.* Ф. Әмирхан. [*Гайнулла солдат*] *балалары турында озын мыегын сыпыра-сыпыра рәхәтләнеп сөйләргә ярата торган иде.* А. Әхмәт.

2. *бот.* Мыекка охшаган үсенте, мыекча. *Игеннәр серкәләнер чак җиткәч, алар доктор кайчысы белән бодайның мыекларын кыркып йөри торган булдылар.* Г. Бәширов. || *сөйл.* Бакча җиләгенең үрчү үрентесе.

◇ **Мыек астыннан көлү (елмаю)** — астыртын көлү. *Җиһанша җизни үзе дә мыек астыннан гына көлеп утырды.* Һ. Такташ. **Мыек кабарту (күпертү)**— 1) ачулану, куркытырга тырышу. *Ата үзенең кыскартылган мыекларын кабартты,* [*ачулы итеп кычкырды*]. Ф. Әмирхан; 2) мактанып, һаваланып йөрү турында. *Габделбәр, мыекларын хәтәр күпертеп, әре генә чиерттерә чиерттерүен.* М. Шабай. **Мыек та селкетмәү** — ис китмәү.— *Арытырсың Сәлим абзыйны, мыегын да селкетми ул.* Ш. Камал. **Мыек тибү** — мыек чыга башлау. *Мыек тибә башлаган егет кеше гомере буе ата канаты астында ятмас.* С. Рафиков. **Мыек чуалу** — 1) кәефсезләнү. *Начальникның мыегы чуалган көн икәнен белепме, башкалар аның күзенә чалынмаска тырыштылар.* А. Гыйләҗев; 2) эш көйсезләнү, эшнең рәте китү. **Мыек чуалту** — эч пошырып, ачу китереп, буталып, комачаулап йөрү.— *Дөрес, ул һич нигезе булмаган гайбәт кенә, ләкин әнә Нургали абыеңның мыегын чуалтыр өчен җитә калган.* Ә. Еники. **Мыек чыгу** — 1) яше җитү, балигъ булу. *Безнең авылда борын астына сызылып мыек чыга башлаган егетләр язны кыз чыгарып каршылыйлар.* А. Шамов; 2) тузу. *Ул мыеклары чыккан чабата кигән иде.* М. Гафури. **Мыекка урау (чорнау)** — истә калдыру, хәтергә салу. *Абыйның ничегрәк эшләгәнен күреп, мыекка урардаен мыекка урап кайтырга исәп.* Ф. Хөсни.— *Бу — ялгыш. Сез моны башта ук мыегызга чорнагыз.* А. Расих.

МЫЕКЛАЧ *и.* **1.** *сөйл.* Мыеклы кеше.

2. *к.* мыеклы балык.

МЫЕКЛЫ *с.* Мыегы булган. *Гарәфинең кыска сары мыеклы йөзенә сагыш күләгәсе йөгерде.* Г. Әпсәләмов.

Мыеклы балык — карплар семьялыгыннан булган елга балыгы; русчасы: усач. *Камбала, чуртан*

балыклары, мыеклы балык һәм елан балыгы да нәкъ шулай ук пещерелә. Йорт эшләре.

МЫЕКСЫЗ *с.* 1. Мыегы юк, мыегы булмаган. *Сөнгать — мыексыз, яшь кенә матур егет.* М. Фәйзи.

2. Яшь, балигъ булмаган. *Гүяки аның каршында мыексыз яшь командир түгел, ә зур соры күзле, акыллы карашлы Гайнулласы басып тора иде.* А. Әхмәт.

МЫЕКЧА *и.* Мыекка охшаган үсентеләр (мәсәлән, кыярда).

МЫЕКЧАН *и. к.* мыеклы. *Адрес була кыекчан. Егет була мыекчан.* Җыр.

МЫЖ *с.* Чиксез күп, бик ишле булуны аңлата. [*Йосыфларның*[*казаннарында быкыр-быкыр ботка пешә. Әйләнә-тирәсендә мыж тараканы.* Г. Гобәй.

◇ **Мыж килү (итү, кайнау)** — нәрсәнең дә булса артык күп булып, ыгы-зыгы килеп торуы турында. *Нурыйның күптән аерылган зур улы Төхфәт белән аның хатыны Мәрфуга, өченче чанада Шәйхел, кунак килен Мәрхәбәләр мыж килеп кайнаштылар.* Г. Ибраһимов. *Халык монда, кырмыска оясыдай, мыж кайный.* Г. Кутуй.

МЫЖГАК *с. диал.* 1. Пычрак, яңгырлы. *Кырык бишенче елның мыжгак көзе иде.* Каз. утл.

2. Бертуктаусыз сукранып, ачуланып торучан; *к. мыжык. Мыжгак карчык.* | *и. мәгъ.* Шундый кеше.

МЫЖГУ *ф.* 1. Мыж килү. [*Буа тирәсендә*] *алтын юучы хатын-кызлар һәм ирләр мыжгып эшлиләр иде.* М. Гафури. *Төрле якта кешеләр, безнең кебек үк җир каера, мыжгып, хәрәкәтләнеп торалар.* Ш. Камал.

‖ 2. *диал.* Сукрану, сукранып тору; „мыж-ж-ж“ кебек авазлар чыгарып, ишетелер-ишетелмәс яки аңлаешсыз итеп сөйләнү. *Окоптагы солдатлар, йокы исереклегеннән нишләргә белмичә, ничек туры килсә шулай мыжгыйлар.* Сов. әд.

◇ **Мыжгып тору** — 1) нәрсәнең дә булса бик күп булуы турында. [*Иске авыл*] *урынына колхозлы, кызыл почмаклы, газета-журналлы, шул ук вакытта әчке каршылыклары да әле мыжгып торган яңа авыл туып килә иде.* Ф. Хөсни; 2) ыгы-зыгы килеп тору. *Тирә-як яшеллеккә күмелгән җирдә, агач башларында кыргый маймыллар көтүе мыжгып тора.* М. Мәхмүтов.

МЫЖГЫЛДАУ *ф.* 1. *к.* мыжлау (1 мәгъ.). *Җәй буе мыжгылдап торган кырмыска оялары әкияттәге алтын чүмәләләргә охшап калганнар.* М. Рафиков. [*Григорийның*] *әчендә еланнар мыжгылдап ятсалар да, ул аны тышка чыгармаска тырыша.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. „Мыж-мыж, мыж-ж-ж“ кебек авазлар чыгарып, еламсырап яки зарланып, аңлаешсыз итеп сөйләнү. [*Нәҗия*] *балалар туздырып ташлаган әйберләрне җыештырып уза, сагынуларын төрлечә мыжгылдап белдерүче балаларны да көйли.* Р. Төхфәтуллин.

МЫЖГЫЛДЫК *и. сөйл. к.* мыжгак *(2 мәгъ.).* ‖ Еламсырап яки зарланып торучан кеше.

МЫЖЛАУ *ф.* 1. Мыж килү, мыжгу. *Кечкенә пионерлар --- атлар белән сабанчылар тирәсендә мыжлап йөрделәр.* Г. Гобәй. *Базар кырмыска оясы кебек мыжлап тора.* К. Нәҗми.

2. *к.* мыжылдау.

МЫЖ-МЫЖ, МЫЖ-Ж-Ж *аваз иярт.* Берөзлексез ишетелер-ишетелмәс килеп торган яки аңлаешсыз булган авазлар җыелмасын белдерә.

◇ **Мыж-мыж килү** — 1) мыжгу, ыгы-зыгы килү. 2) *к.* мыж-мыж сөйләнү. **Мыж-мыж сөйләнү** — берөзлексез, бертуктаусыз эчпошыргыч итеп сөйләнү яки бертуктаусыз сукрану. *Мыж-мыж килеп сөйләнгән кешедән өмет өз.* Мәкаль.

МЫЖЫК *с.* Һәрвакыт сукрануучан кеше турында әйтелә. *Элегрәк кызын күргән саен битәрләп, аның янында һаман кирле-мырлы сөйләнеп бара торган мыжык ата хәзер Нуранияга сүзсез буйсынып кына бара.* М. Әмир.

МЫЖЫЛДАУ *ф.* Сукрану. *Аңа бу карчыкның юк-бар турында мыжылдаулары хәзер бик кечкенә нәрсә булып калганга охшый.* Г. Бәширов.

МЫЗЫЛДАУ *ф. к.* бызылдау.— *Черки бар җирдә күп булдым, аның мызылдаганына карап йокламый да калмадым.* Ш. Мөхәммәдев.

МЫЙКЫЛДАУ *ф.* Артык таза кешенең һәм бик симез хайваннарның итләү урыннары селкенеп тору турында. *Янбашлары мыйкылдый.*

МЫЙКЫЛДЫК *с.* Симез. *Мыйкылдык тән.*

МЫЙКЫЛ-МЫЙКЫЛ: мыйкыл-мыйкыл итү — *к.* мыйкылдау.

МЫЙМЫЛДАТУ *ф. Мыйкылдату, мыймыл-мыймыл иттерү. Теш казнаңны селкетсәң, сөяксез телеңне кыймылдатсаң, иреннәреңне мыймылдатсаң, өрелә дә чыга ул сүз.* А. Гыйләҗев.

МЫЙМЫЛДАУ *ф.* 1. *к.* мыйкылдау.

2. Хәрәкәтләнү рәвеше турында әйтелә. *Сынадым* [*исәп*] *уеңны, Авызың дәхи былбылдай. Зифа буең, төсең-битең, Ки хур кызыча мыймылдый.* Г. Кандалый.

МЫЙМЫЛДЫК *с. к.* мыйкылдык. ‖ *и. мәгъ.* Симез кеше.

МЫЙМЫЛ-МЫЙМЫЛ: мыймыл-мыймыл итү — *к.* мыймылдау 1.

МЫЛТЫК *и.* Озын көпшәле ату коралы. *Крестьяннар, тавышлар басылгач кына, мылтыкларын тотып, ярык-йорыклардан урамга карый башладылар.* Һ. Такташ. *Стеналар ялангач, тик бер якта ике көпшәле мылтык, бер револьвер вә берничә кием эленгән.* Ш. Камал.

МЫЛТЫКЛЫ *с.* Мылтыгы булган, кораллы. *Мылтыклы солдат.* ‖ Мылтык төялгән. *Мылтыклы өч көймә безнең ярга якынлашты.* Ф. Әмирхан.

МЫРАУ *аваз иярт.* Мәче кычкырган калын тавышны белдерә.

МЫРАУЛАУ *ф.* Мырау-мырау итү, калын тавыш белән кычкыру (мәче турында). *Аяк астында, Зиннәткә сыенып китә-китә, мәче мыраулап йөри.* А. Шамов.

МЫРКЫЛДАУ *ф.* 1. Мыр(ы)к-мыр(ы)к килү, мыр(ы)к-мыр(ы)к итү. [*Дуңгызлар*] *үзләре актарган туфракка ятканнар да әкрен генә мыркылдыйлар.* Г. Әпсәләмов.

2. *кимс.* Өзлексез сукрану, ачуланып сөйләнү турында.

МЫРКЫЛДЫК *и. сөйл.* Дуңгыз.— *Станция халкы бик тә файда итә икән ул мыркылдыклардан.* Р. Төхфәтуллин.

МЫРЛАУ *ф.* 1. Мыраулау.

2. *күч.* Йоклау, гырлау. *Ялгызлыктан газапланган Илсөяр тәрәзә төбендә кояш нурларында гамьсез мырлап яткан песине кереп кузгатты.* Г. Гобәй.

3. Җырлаган сыман итү, көйләү. [*Давыт*], *җиңел көйгә мырлый-мырлый, урам буйлап китеп тә бара.* А. Гыйләҗев.

МЫР[Р]-МЫР[Р] *аваз иярт.* 1. Мәче мыраулаган тавышны белдерә. *Кич булу белән песи Нәсимәнең юрганы астына керә дә, мырр-мырр итеп, йомшак кына көйли башлый.* Д. Аппакова.

2. Әкрен сөйләгәндә, җырлаганда, йоклаганда чыккан мыр-мыр иткәндәй тавышны белдерә. *Тамакның төпләре гыр-гыр килә, Болгана куллар, авыз мыр-мыр килә.* Ш. Бабич.

МЫР[Ы]К-МЫР[Ы]К *аваз иәр.* Дуңгыз кычкырган тавышны белдерә.

МЫРЫЛДАУ *ф.* **1.** Мыр-мыр килү, мыр-мыр итү, мырлау. *Мәче кабыргасы белән Рифгатьнең аяклары-на ышкыла-ышкыла мырылдарга тотынды.* М. Әмир.

2. *сөйл.* Борын астыннан сөйләнү. || Сукрану, сукранган сыман итү. *Атам юк ырылдарга, Анам юк мырылдарга.* Мәкаль.

МЫСКАЛ *и. иск.* Үлчәү системасы кертелгәнгә кадәр якынча 4,26 граммга тигез булган авырлык үлчәү берәмлеге (кадакның $\frac{1}{96}$ өлеше).— *Ярты кадак арыш ипиенә өстәлеп бирелергә тиешле 24 мыскал күмәч тә бәйрәм чәенә килешә төшә.* К. Нәҗми. *Тастымалың бик җиңел, Килер микән биш мыскал.* Җыр.

◇ **(Бер) мыскал да** — бөтенләй, бер дә, һич тә. [*Нури:*] *Син, карчык, юкны сөйләнеп, баш катырасың! Утыз ел тукыдым, бер мыскал да акыл кермәде үзеңә!* Г. Ибраһимов. **Мыскалга салу** — 1) бик җентекләп, һәр ягын уйлап сөйләү турында. *Акыллы кеше сүзне үлчәп, мыскалга салып сөйли торган була.* Р. Ишморат; 2) артык ваклашу, вакчыллык күрсәтү. **Мыскалы да** — аз гынасы да, бөртеге дә. *Ялантауда тупланган байлыкның мыскалы да дошман кулына әләкмәде.* М. Әмир.

МЫСКАЛЛАУ *ф.* **1.** Мыскал белән үлчәү. || *рәв. мәгъ.* **мыскаллап.** Мыскал белән. *Гәүһәрне мыскаллап үлчиләр.* Мәкаль. || *күч. сөйл.* Ваклап, бөртекләп. *Комиссия бөртекләп җыя бит ул, мыскаллап!* Г. Бәширов. *Мыскаллап-мыскаллап җыелган колхоз байлыгы әкренләп арта бара.* Каз утл. || *күч.* Бик акрын; азлап-азлап. *Батманлап кергән авыру мыскаллап чыгар.* Мәкаль.

2. *күч. сөйл.* Саранлану, артык вакланү.

МЫСКЫЛ *и.* Мәсхәрә, мәсхәрәләп көлү. [*Захаровның*] *тавышында ниндидер явыз тантана, зәһәрле мыскыл һәм шуның белән бергә шатлык та бар иде.* А. Шамов. || Кимсетү, хур итү. *Тел белән әйтеп бетермәгән ниндидер бик зур мыскыл бар иде бу* [*Нигъмәтнең*] *хәрәкәтләрендә.* Ф. Хөсни.

◇ **Мыскыл итү** — 1) мәсхәрәләп көлү, мәсхәрәгә калдыру.— *Мине һаман мыскыл итәсең, мин сиңа чынлап сөйлим, э син һаман миннән көләсең.* Г. Камал; 2) мәсхәрәләү, хурлау.— *Сугыш дигәне, адәм баласының иң нечкә, иң мөкатдәс тойгыларын мыскыл итеп, кемдер әйтмешли, пычракка салып таптый.* Г. Бәширов; 3) кызларга карата: көчләү, алдау, хур итү. [*Гәрәй Фәхриягә:*] *Теге жуликтан саклан, ул сине мыскыл итәргә азаплана.* Ш. Камал.

МЫСКЫЛЛАУ *ф.* **1.** Мәсхәрәләү, мәсхәрәләп көлү. *Таһирның гармонь көенә Гөлнарны мыскыллап җырлаганы ишетелде.* Ә. Айдар. *Теге ак чырайлысы, ике кулы белән бөренә таянган килеш, һаман мыскыллавында дәвам итте.* Г. Бәширов.

2. Көчләү, алдау. [*Ул крестьян*] *махночының хәрби кием кигән ниндидер бер кызны Днепр буенда хур иткәнен, мыскыллаганнан соң суга ташлаганын күргән.* А. Шамов.

МЫСКЫЛЛАУЛЫ *с. к.* мыскыллы. *Мыскыллаулы караш.*

МЫСКЫЛЛЫ *с.* Мыскыл итә торган, мыскыллау белдерә торган, мәсхәрәле. *Бүлмәдәгеләрнең берсе мыскыллы тавыш белән: „Сезгә кем кирәк?“ — дип сорады.* Каз. утл.— *Иң алдагы сафта утырган Низамның миңа карап мыскыллы елмаю күрсәтүе мине эсселе-суыклы итеп җибәрде.* М. Әмир.

МЫШКЫЛДАУ *ф.* **1.** Нәрсә дә булса эшләгәндә, йөгергәндә, ашыкканда еш-еш сулап, „мыш-мыш“ авазлары чыгару. *Беркөнне кич Салават мышкылдап кайтып керде дә Мәрфуга Минвәлиеваның больницага әлгүен әйтте.* Г. Ахунов.

2. *сөйл.* Көч кую, көч сарыф итү, көчәнү. *Малайны чокырдан чыгару өчен Сәфәргалигә күп кенә мышкылдарга туры килде.* Ф. Хөсни. || Ару, тын бетәр чиккә җитеп хәлдән таю. [*Иптәшләре дә*] *Нуруллин шикелле үк арыганнар, тирләгәннәр, мышкылдаганнар.* А. Шамов.

3. Мышык-мышык итеп елау.

МЫШКЫЛДЫК *и.* Мышный, мышкылдый, әкрен кыймылдый торган кеше.— *Кая инде ул мышкылдыкка безне куып җитү.* Г. Бәширов.

МЫШ-МЫШ *аваз иәр.* **1.** Ашыкканда, йөгергәндә, авыр эш эшләп арыганда еш сулаудан барлыкка килгән авазларны белдерә.

2. *к.* мышык-мышык. *Күрше бүлмәдә берәүнең мыш-мыш елаган тавышы килә шикелле булды.* Ф. Әмирхан.

◇ **Мыш-мыш килү** — *к.* мышнау. *Мыш-мыш килеп атны куасың.* М. Җәлил. *Әти чайкала-чайкала урындыкны күтәреп маташа, үзе мыш-мыш килә иде.* Р. Төхфәтуллин.

МЫШНАУ *ф.* Мыш-мыш тын алу, мышкылдау. *Мулла, алдына куелган савытны күрмичә, авырайган башын аска төртеп, сәждәгә китәр-китмәс, сыер кебек мышнап утырды.* И. Гази. | *рәв. мәгъ.* **мышный-мышный.** *Ул үзенең эштә пычранган итеген мышный-мышный салды да өйалдына күтәреп чыгып китте.* Ә. Фәйзи.

МЫШТЫМ *с.* **1.** Астыртын. *Мыштым кеше.*

2. Тыныч, салмак, акрын (кеше турында). || *и. мәгъ.* Сүзсез, күп сөйләргә яратмаучы кеше.— *Тыңлап утыручылар арасында дегетче Хәйдәршаның уртанчы улы да бар иде. Кем уйлаган бит шул мыштымның эчендә агу кайнаганын.* Х. Садрый.

◇ **Мыштым гына** — акрын гына, сиздермичә. *Миңнур карт, урынныннан торып, өйалдына мыштым гына чыгып китте.* А. Шамов. *Мыштым гына әңгәмәне икенче якка борып җибәрәбез.* А. Расих.

МЫШТЫР *рәв.* Акрын. *Иртә дә мыштыр, кич тә мыштыр.* Мәкаль.

МЫШТЫРДАУ *ф.* Акрын кыймылдау, нәрсәне дә булса бик акрын, озак эшләү турында. *Тозга баручы авылдашларын ул басу капкасы төбендә куып җитте: тагын бераз мыштырдаса, бөтенләй өлгермисе икән.* И. Гази. || Нәрсә белән дә булса шөгыльләнү. *Кайчакларны кичен, ятарга җыенган булып, кровать тирәсендә арлы-бирле мыштырдый да --- идәнгә генә төшеп ята торган иде ул.* Г. Бәширов.— *Яшьләр ГРЭС ягына табыналар. Без, картларча, өйдә мыштырдыйбыз, колхозда.* А. Гыйләҗев.

МЫШЫК-МЫШЫК *аваз иәр. к.* лышык-лышык. *Яңа күршенең яшерен генә мышык-мышык сулкылдавы ишетелеп куйды.* Ш. Маннур.

МЫШЬЯК *и. хим.* **1.** Кайбер минераллар составына керә торган химик элемент, көчле агулы матдә.

2. Шул матдәдән ясалган препарат, медицинада һәм техникада кулланыла. || *с. мәгъ.* Мышьяктан алынган. *Мышьяк кислотасы.*

МЫШЬЯКЛЫ *с.* Составында мышьяк булган. *Мышьяклы рудалар. Мышьяклы тозлар.*

МЫЖЫРДАУ *ф.* Ачып, күпереп утыра торган бал, квас һ. б. ш. турында әйтелә. *Мыжырдап торган гайрәтле ачы бал.*

МЫЖЫР-МЫЖЫР *аваз иәр.* Нәрсәнең дә булса ачып, күпчеп, куыклар чыгарып мыжырдаган тавышын белдерә.

МЫҢГЫРДАУ *ф. к.* мыгырдау.

МЫҢГЫР-МЫҢГЫР *аваз иәр. к.* мыгыр-мыгыр.

МЭР *и.* Кайбер чит илләрдә: муниципалитет идарәсе башлыгы. *Лондон мәры шәһәр капкаларын ябарга кушкан.* Урта гас. тарихы.

МЭ'РИЯ *и.* Муниципалитет идарәсе; шул идарә урнашкан бина.

МЮЗИК-ХОЛЛ *и.* Эстрада театры. *Мәскәү мюзик-холлы.*

МӘ *хәб. сүз.* **1.** Ал, кулыңа ал, тот.— *Мә сиңа биш тиен, минем кибеткә кереп прәннек алырсың.* Ә. Фәйзи.— *Мә, Айсылу апа, халык каршысына байракны син алып кер!* Г. Бәширов. || Нәрсәгә дә булса ирек бирү, рөхсәт итү сүзе булып кулланыла. *Кычкырды ул чыгып Сафлар арасыннан:— Дй, кабахәт дошман! Мә, күкрәгем, мә ат!* Ә. Исхак.

2. Кыйнаганда, сукканда, әйберләр атып-атып бәргәндә әйтелә. [*Гәрәй:*] *Мә күзеңә! Мә борыныңа! Мә авызыңа! (Чикләвек, бәрәңге кебек нәрсәләр ата).* М. Фәйзи.

◇ **Мә сиңа (кирәк булса)** — көтелмәгән хәлдән аптырап калуны белдерә. *Мә сиңа кирәк булса, [Хәйрүш] велосипед алган!* М. Җәлил.

МӘГАРИФ *и.* **1.** Гыйлем, белем, аң-белем, мәгърифәт. *Дүвәлдә наданлыкка сырган кебек, Ушбу чакта мәгарифкә сырышырга.* Г. Камал.

2. Уку-укыту, аң-белем бирү. *Татар мәгарифе мәсьәләсенең кирәгенчә хәл ителүен теләгән затлар моны [Россиянең яңаруын] теләргә мәҗбүрләрдер.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Мәгарифкә мөнәсәбәтле. *Мәгариф министрлыгы.* □ *Халикъ шәһәр мәгариф бүлеге башлыгы булып эшли иде.* Ш. Усманов. || Культура. *Дәлил булдың бу көндәге мәгарифкә.* М. Гафури.

МӘГАРӘ *и.* **1.** Тау тишеге. *Бик хәтәр урманнар, сазлыклар һәм мәгарәләр аркылы узам.* М. Җәлил. *Вагон эче әкиятләрдәге серле мәгарәне хәтерләтә башлады.* А. Гыйләҗев.

2. *күч.* Мәгарәгә охшаган караңгы, юеш торак урын.

МӘГЪДӘН *и. иск.* **1.** Руда, металл, казылма байлык. *Тормыш белән техниканы бер-берләренә аралаштыру өчен каты мәгъдәннәрне теләгән рәвешкә китерү юлында җитез куллар станокларга, станоклар кулларга булышлык итәләр.* Ш. Камал.

2. Рудник, шахта. *Мәгъдән корольләре башлаган сугышның җимереклеген әле адәм балалары үз өсләреннән уздырганнары юк.* Ф. Әмирхан.

МӘГЪЗУР *и. иск.* **1.** Гозерле, гозер иясе. *Онытмачы, Кави, мәгъзур колыңны.* М. Җәлил.

2. Нинди дә булса сәбәп белән берәр эшне, йомышны үти алмаучы.

МӘГЪКУЛЬ *с. кит.* **1.** Лаек, лаеклы, кулай. [*Әхмәтҗан:*] *Шәм шикелле иелми-бөгелми торган, үрәгә катkан нәрсә булгач, бер дә мәгъкуль кеше түгел икән.* Г. Камал.— *Чыннан да бу олан бик мәгъкуль икән.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *рәв. мәгъ.* Акылга сыярлык итеп, ышанырлык итеп. *Акыл әйтсәң, мәгъкуль әйт.* Мәкаль. || *хәб. функ.* Ризалыкны, хуплауны белдерә: яхшы, хуп. [*Хажи:*] *Мәгъкуль, җаным, бик мәгъкуль.* Ш. Камал.

Мәгъкуль булу — урынлы булу; уңай булу. [*Мәдинә белән*] *ни хакында сөйләшү мәгъкуль булыр икән?* Ш. Хөсәенов. **Мәгъкуль күрү (табу)** — хуплау. *Шәриф Җәмиләне өйдәш итеп кертүне мәгъкуль күрмәде.* М. Гафури.

МӘГЪЛҮМ *с.* **1.** Билгеле, билгеле булган, гадәттәге, таныш. *Пычкы бер күтәрелеп, бер төшеп торган уңайга Газинурның күз алдындагы киң кыр да, карасу-яшел урман да мәгълүм бер ритм белән тибрәнергә тотынды.* Г. Әпсәләмов. || *хәб. функ.* Билгеле, таныш. *Бармы чиге бу киңлекнең, юкмы, белмим, Тик шул мәгълүм: Менә күпме вакыт инде, барам, барам, Күз күремем җиткәне юк әле һаман.* З. Мансур.— *Минем ул бала өчен теләгән теләкләрем, ул бала өчен биргән нәзер-ниятләрем бер ходайның үзенә генә мәгълүм.* Г. Камал.

2. *и. мәгъ.* **мәгълүмең, мәгълүмегез.** Белгән, таныш кешегез; танышыгыз.

◇ **Мәгълүм булу** — ачыкланy, билгеле булу. *Тик көндезге сәгать уникеләрдә генә 250 кешелек бөтен бер ротаның югалганлыгы мәгълүм булды.* М. Гали. **Мәгълүм итү** — белдерү, хәбәр итү.— *Кадерле атам, сезгә шуны мәгълүм итәем: юкка гына мине бу мәдрәсәгә җибәрдең, тәртип-низам юк, гыйлем алуны уйларга да ярамый.* Т. Гыйззәт.

МӘГЪЛҮМАТ *и.* **1.** Аң-белем, белем, гыйлем. *Институт иҗтимагый фәннәр буенча тирән мәгълүмат бирә.* Каз. утл. *Ул башкалар кебек җитәрлек мәгълүмат, иҗтимагый тәрбия дә алмаган.* Г. Нигъмәти. *Мәдрәсәдә уналты яшенә кадәр укыган булса да, аның мәгълүматы бик сай иде.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Хәбәр, материал. [*Егет*] *завод тарихына кагылышлы мәгълүматларны җыеп туплый иде.* Соц. Тат.— *Разведкадан нинди мәгълүматлар алып килделәр икән?* А. Шамов. || Белешмә.— [*Бу йортларның ничек салынулары*] *турында без волкомга кереп шактый вакыт сөйләшеп утырганның соңында гына тулырак мәгълүмат ала алдык.* М. Әмир.

МӘГЪЛҮМАТЛЫ *с.* **1.** Белемле, укыган, күп белә торган.— *Менә тиздән гали мәгълүматлы кешеләребез өлгерәчәк.* Г. Тукай.

2. Нәрсәдән дә булса хәбәрдар. *Бу мәсьәләдә абый иң мәгълүматлы кеше санала.* Каз. утл.

МӘГЪНӘ *и.* **1.** Әйтергә теләгән фикер. *Ул дустының соравы астына яшеренгән икенче мәгънәне аның карашыннан тотып алмакчы булды.* Г. Минский. *Шигырьгә тирән мәгънә бирәм дип, --- аңларга авыр бер хәлгә китерергә тырышу бар — бу да ялгыш юл.* Һ. Такташ. || Сүзнең, атаманың һ. б. ш. эчтәлеге. *Ахирәтем — иң якын иптәшем мәгънәсендә.* М. Җәлил.— *Ничек инде ул алай, Газинур, сөйгән кызың исеменең мәгънәсен белмисең?* Г. Әпсәләмов.

2. Мөһимлек, әһәмият. *Бу сөйләшүләрнең мәгънәсен ул бары иртәгесен генә аңлады.* А. Шамов. *Ул инде хәзер ананың сүзләрен тыңлый алмый, ул сүзләрнең һәртөрле мәгънәсе югалды.* Ә. Еники. || Иҗтимагый роль. *Тормышның төрле баскычлары аркылы үтеп, хәзерге көрәшнең мәгънәсен чынлап аңладым.* М. Гафури. || Нәрсәдән дә булса файда.— *Монда көтеп утырудан бер тиенлек тә мәгънә чыкмас.* Г. Камал.

3. *сөйл.* Рәт, җай.— *Киленең эшнең мәгънәсен дә, тәмен дә белеп эшли.* Каз. утл. *Эшнең мәгънәсен белеп эшләгән — җиңәр, сүзнең мәгънәсен белми сөйләгән — җиңелер.* Мәкаль.

◇ **Мәгънә бирү** — нәрсә дип уйлау, дип аңлау, берәр хәлгә юрау. *Аның бу эшләренә бернинди мәгънә биреп булмый.* Ш. Хөсәенов.

МӘГЪНӘВИ *с. кит.* **1.** Мәгънәгә караган. *Сүзнең мәгънәви ягы.*

2. Аң белән генә беленгән, эчке, рухи.— *Ирләрдә һичкайчан да, һичкайсында да без уйлаган хәтле мәгънәви матурлык, шигърият булмый.* Ш. Камал. *Китап язу ул — чиксез мәгънәви азык бирә торган күңелле эш.* Х. Кәрим.

МӘГЪНӘДӘШ *с.* Бердәй мәгънә белдерә торган, синонимик. *Мәгънәдәш сүзләр.* || *и. мәгъ.* Бердәй мәгънә белдерә торган сүз (термин, мәкаль һ. б.), синоним. *Тураган телгәнен кабар, ашаган биргәнне*

кабар [*мәкаленең*] *мәгънәдәше: кемнең кулында, шуның авызында.* Н. Исәнбәт.

МӘГЪНӘДӘШЛЕК *и.* Мәгънәдәш булу, синонимик булу, синонимлык.

МӘГЪНӘЛЕ *с.* **1.** Эчтәлекле. *Тормышка бәйләнмәгән абстракт образлар шигырьне матурламый да, тирән мәгънәле дә итә алмый.* Һ. Такташ. *Сүзе тирән мәгънәле һәм Үзе шундый ягымлы.* М. Җәлил.

2. Акыллы, эшлекле, файдалы. *Мәгънәле киңәш. Мәгънәле тәкъдим.* □ [*Газиз:*] *Нинди тирән мәгънәле сүзләр!* А. Әхмәт. | *рәв. мәгъ.* [*Мирсәет:*] *мәгънәле итеп сөйлисең син, Габтелмән абзый.* Р. Ишморат.

3. Күп нәрсә аңлата торган, серле.— *Нинди сөйкемле, нинди йомшак, нинди мәгънәле караш!* Ф. Әмирхан. || *рәв. мәгъ.* Серле итеп.— *Без* [*Гөлбикә*] *белән беренче мәртәбә бик мәгънәле карашып алдык.* Г. Ибраһимов. *Егет, кызның кулын мәгънәле кысып, икенче кулы белән аны кочаклап алды.* К. Тинчурин.

МӘГЪНӘСЕЗ *с.* **1.** Килешмәгән, килешсез; урынсыз. *Халикъ бу мәгънәсез сорауга җавап биреп тормады.* Г. Әпсәләмов.

2. *рәв. мәгъ.* Буш, эчтәлексез. *Шулай мәгънәсез узып торган бик күп көннәрнең берендә аның күңел бушлыгына Нәфисә килеп керде.* Г. Бәширов. || Файдасыз. *Гомер буе мәгънәсезгә аккан суны Бөяп куеп, әйләндереп нурга шуны, Кабызганнар мәңге сүнмәс Ильич утлары.* Ә. Исхак.

3. Бүталчык, аңлаешсыз. *Ул әллә нинди мәгънәсез төшләр күреп саташып чыкты.* Ш. Камал.

4. Акылсыз, аңгыра. *Ни мәгънә бар булуда башың такыр, Эчендә миең булса чокыр-чакыр. Мәгънәсез баш никадәр зур булса да, Уты-суы булмаган бер дала-кыр.* Г. Камал. || Мәнсез, мән (II), мәгънә (3 мәгъ.) белми торган. *Мәгънәсез кеше.*

МӘГЪНӘСЕЗЛЕК *и.* Мәгънәсез булу сыйфаты, хәле. [*Габдулла*] *елап утыруның мәгънәсезлеген һәм фәнгә омтылырга кирәклеген аңлатып, ике юллык үткер генә шигырь әйтте.* Ә. Фәйзи. || Акылсызлык. *Мәрьям фаҗигасен артык күңелсез һәм төштә дә күрмәслек бер мәгънәсезлек итеп санадылар.* Г. Нигъмәти.

МӘГЪНӘСЕЗЛӘНҮ *ф.* Мәгънәсезгә әйләнү.

МӘГЪРИП *и. иск. кит.* Көнбатыш. *Тавышыңны ишетер мәшрикътән Мәгъриптә булган кеше.* М. Гафури. *Аның ике тәрәзәсе бар, берсе мәгърипкә, берсе мәшрикъкә карый.* Ш. Еникеев.

МӘГЪРИФӘТ *и. кит.* Белем, аң-белем һәм культура. *Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.* Г. Тукай. *Тән азыгы — икмәк, җан азыгы — гыйлем һәм мәгърифәттер.* Мәкаль.

МӘГЪРИФӘТЛЕ *с. кит.* Белемле, укыган. *Себер бае — шәһәргә өйләнергә килгән, 35 яшьләр чамасы, --- мәгърифәтле бер кеше.* Г. Камал.

МӘГЪРИФӘТЧЕ *и. кит.* Аң-белем таратучы; галим, гыйлем иясе. [*Мансуров Хәйдәргә:*] *Син әле һаман да шул элекке азу ярган мәгърифәтчеме?* Г. Бәширов. *Татар мәгърифәтчеләренең күренекле вәкиле булган Каюм Насыйриның эшчәнлеге халыкчанлык белән сугарылган иде.* М. Гайнуллин.

МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК *и. кит.* **1.** Мәгърифәт өлкәсендә эшчәнлек. *Татар мәгърифәтчелеге. Рус мәгърифәтчелегенең йогынтысы.* || *с. мәгъ.* Мәгърифәтчеләккә бәйле, мәгърифәтчелек турындагы. *Мәгърифәтчелек идеяләре. Мәгърифәтчелек хәрәкәте.*

2. *тар.* XVII—XVIII йөзләрдә Көнбатыш Европа прогрессив буржуазиясенең идея хәрәкәте. || XVIII—XIX йөзләрдә алдынгы рус һәм славян җәмәгатьчелегенең ижтимагый фикер хәрәкәте. || XIX—XX йөзләрдә татар җәмәгатьчелегенең ижтимагый культура хәрәкәте.

МӘГЪРУР *с. кит.* **1.** Горур. *Шатлана мәгърур ана Антын ишетеп сөйгән улының.* Ә. Исхак. *Иркен яшәү өчен хокук алды Безнең илнең мәгърур кешесе.* Ә. Ерикәй. | *рәв. мәгъ. Халык белән бергә көрәшкә һәм Азатлыкка мәгърур атлый ул.* Ш. Маннур. *Иңбашына пәрдәләрен салган да ул, Карый мәгърур, яшерен уйга талган да ул.* Ф. Бурнаш.

2. Масайган, тәкәббер, эре. *Кайда боз канлы мәгърур кар кызы? Акты сөйгәне куенында әреп.* М. Җәлил.

3. Нәрсәгә дә булса алданган, табынган, башкаларны күрмәс дәрәҗәгә килгән. [*Сыймас идең*] *киң җиһанга, малыңа мәгърур булып.* Г. Тукай.

МӘГЪРУРАН(Ә) *рәв.* **1.** Горурланып, горурлык белән. *Кояш мәгъруранә кызару белән кызарып бата.* Ф. Хөсни.

2. Вәкарь белән, эреләнеп, тәкәбберләнеп. *Ялгызы алдан бара иблис пәри; Мәгъруранә, фахиранә* [*мактангандай*] *төсләре!* Ш. Бабич.

3. Нәрсәгә булса да алданып, табынып.

МӘГЪРУРЛАНУ *ф.* Эреләнү, тәкәбберләнү.

МӘГЪРУРЛЫК *и.* Горур, мәгърур булу сыйфаты.

МӘГЪСУМ *с. иск.* Гөнаһсыз, саф, керсез күңелле.— *Гөнаһлы ана белән мәгъсум баланың сыкрауларын бу көзге җилләр сиңа ирештермиме?* М. Фәйзи. *Ул гүзәллеккә чумган мәгъсум бер бала иде әле.* Ш. Камал.

МӘГЪСУМАНӘ *рәв. кит.* Гөнаһсыз (көе), саф, керсез күңел белән. *Исемдә курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар, Гафифанә (саф) вә мәгъсуманә көлгән, уйнаган чаклар.* Г. Тукай.

МӘГЪСУМЛЕК *и. кит.* Гөнаһсызлык, сафлык, күңел керсезлеге.

МӘГЪШУК[А] *и. кит.* Сөйгән яр. *Мин гарип мең кат янып та — Яндыга саналмадым; Уйлагыз: мәгъшука меңнәр! Мин гашыйк саналмадым!* Дәрдмәнд. *Хәлил, башы белән Сөләйманга таба изәп: [Бу кыз аның] мәгъшукасы булырга кирәк, — диде.* К. Тинчурин.

МӘГЫЙШӘТ *и. кит.* Тормыш, көнкүреш, тереклек итү. *Галиҗәкәр әфәнде бу әсәрен хосусый бер гаиләнең мәгыйшәтеннән алып язган.* Ф. Әмирхан. [*Җәмилә апасы биргән нәрсәләрне*] *тотып-тотып карый, мәгыйшәте тәмам тәэмин ителгән кешеләрчә шатлана иде.* М. Гафури.

◇ **Мәгыйшәт итү (кылу)** — яшәү, тереклек алып бару. *Мәгыйшәт кылыр өчен һәрберебез бер рус кадәр русча сөйләшергә, укырга, язарга* [*белергә*] *тиештер.* Ш. Мөхәммәдев.

МӘГӘР *терк. иск.* **1.** Тик, ләкин, әмма. *Кем булса да булсын, мәгәр хәере белән генә тусын, — диде анасы һәм кызының маңгаеннан үбеп алды.* А. Шамов.— *Тау — тауга килмәс, мәгәр адәм адәмгә очрар, дигәннәр.* Г. Ибраһимов.

2. Шулай, шулай да, шулай итеп. *Мәгәр карт көтүче үзе артык картайгач, үзе урынына көтү көтәргә ике кызын җибәрә башлаган.* Г. Гали. —*Мәгәр җиңел чыктык бит.* Сов. әд.

МӘДЕХ *и. иск.* Мактау. *Мәдехсез дә бәһадир мәшһүр була.* М. Гафури. *Сакчыны зур мәдехкә күтәрәләр.* Әкиятләр.

◇ **Мәдех итү (кылу)** — *к.* мәдехләү.

МӘДЕХЛӘҮ *ф. иск.* Мактау, зурлау. *Берәм-берәм аеруча шигырь берлә Мәдехләрбез Россия илебезне.* М. Гафури.

МӘДРӘСӘ *и. кит.* Мөселманнарда: урта һәм югары класслары булган дини уку йорты. *Сөләйманның*

Сәетзадә белән танышлыгы мәдрәсәдән бирле килә. К. Тинчурин.

МӘДХИЯ *и. кит.* **1.** Мактау сүзе. *Интәшләрдән аңа төрле-төрле мәдхияләр ява.* М. Гафури.

2. Мактау җыры, ода. *Чәчәккәйләр, сезгә бер үтенеч: Мөмкин булса, рөхсәт бирегез... Тәмле исегезгә исергәндә, Мәдхияләр җырлап йөрермен.* Ш. Бабич. *Саша күбрәк мәдхияләр яза иде. Сугыш көннәрендә ул --- әллә нихәтле мәдхияләр язды.* Э. Касыймов.

◇ **Мәдхия уку** — мактау, күкләргә күтәрү.

МӘДХИЯЧЕ *и. иск.* **1.** Мактап сөйләүче, мактап җырлаучы.

2. Мәдхия (2 мәгъ.) язучы, ода язучы.

МӘДӘНИ *с. кит.* Культуралы, алдынгы.— *Бу бокалымны мин авылыбызның мәдәни көчләре исәнлегенә күтәрәм.* М. Әмир.

МӘДӘНИЛЕК *и. кит.* Культуралылык, алдынгылык.

МӘДӘНИЛӘШТЕРҮ *ф. кит.* Мәдәниятле итү, культуралаштыру.

МӘДӘНИЛӘШҮ *ф. кит.* Культуралашу. [*Гөлбикә*] *бераз үзгәргән, бераз мәдәниләшкән, өстендә әлекке башкорт җиләне урынында хәзер тәннәрен кысып --- торган чибәр генә пальто.* Г. Ибраһимов.

МӘДӘНИЯТ *и. кит.* Культура. *Алар хәзерге көндә --- яңа шахтерлар кадры, белем, мәдәнияткә сусаган забойщиклар кадры булып киткәннәр.* Һ. Такташ. *Рус әдәбияты, рус мәдәнияте әчендә азыкланганга,* [*Паларусовка*] *татар теленнән русныкы җиңел иде.* Г. Ибраһимов.

МӘДӘНИЯТЛЕ *с. кит.* Культуралы; алдынгы, укымышлы. *Мәдәниятле тормыш. Мәдәниятле кеше.*

МӘЕЛ *и. иск.* **1.** Теләк, кызыксыну. *Халыкның барлык мәелләре, гадәтләре, акылы-фигыле аның мәкальләрендә үзенчәлекле чагыла.* Н. Исәнбәт. || *тарт. форм.* **мәйле (ң, гез).** „Теләге, теләгең, теләгегез, ихтыярыгыз, сезнең иректә“ кебек мәгънәләрне аңлата.

2. *бәйл. функ.* Нәрсәгәдер якын, тартым булу мәгънәсен бирә. [*Йолдыз*] *үзенең карага мәел чәче, ак, нәфис һәм балкып торган йөзе --- белән бөтен авылның кешеләрен гажәпкә калдыра.* Ш. Әхмәдиев.

◇ **Мәел итү** — авыштыру, бирү. *Шуннан соң күңелен ул әшкә бигрәк тә мәел итте.* З. Һади.

МӘЕТ *и.* Үлек, үлгән кеше гәүдәсе. *Мәетләрне инде күмгәннәр, тик ат үләксәләре генә, козгыннарга азык булып, кырда сибелеп яталар иде.* Ш. Усманов.— *Олы мәетнең һәрвакыт казасы була: я ат үлә, я сыер...* И. Гази.

Мәет арбасы — мәетне кабергә алып бару өчен махсус арба, катафалк. *Дүрт ат җигелгән теге мәет арбасы әкрен генә кузгалып алга бара башлаган.* М. Гафури.

◇ **Мәет чыккан төсле (шикелле)** — күңелсез, караңгы, шомлы тынлык булганда әйтелә.— *Син булмагач, өйдә дә күңелсез, мәет чыккан шикелле.* Г. Бәширов.

МӘЗ: мәз бетү (китү) *диал.* — мөкиббән китү (булу). *Бабай, калкавычларына текәлеп, шул кадәр мәз беткән иде,— ул Садыйкка игътибар да итмәде.* А. Расих.

МӘЗИН *и.* Мәчеттә азан әйтүче дин әһеле.— *Без чатан мәзиндә сабак укып йөри идек.* М. Әмир.

МӘЗКҮР *с. иск.* Югарыда әйтелгән, югарыда күрсәтелгән, әйтеп үтелгән. *Күрәсез, укыйсыз, ләкин мәзкүр журналда бер бик кызыклы нәрсәне күрми калдырасыз.* Г. Тукай.

МӘЗӘК *и.* **1.** Шаярып, уйнап әйтелгән сүз, уенчак сүз. [*Кыз*] *очрашкан чакларда елмаеп, көлеп сөйләшә, мәзәкләремне дә күтәрә иде.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Шаян, көлке, уенчак, уйнап әйтелгән. *Шаянлыгы, мәзәк сүзләре, яхшы иптәш булуы белән ул үзен бик тиз таныттты.* Г. Бәширов.

2. Анекдот. *Монда һәр елны урак өстендә яшьләр-кызлар арасында төрле мәзәкләр чыгаруда танылган Идрис карт та бар.* Г. Минский.

3. Кызык хәл; кыланыш. *Берни булса, замандашлары аның яшь чактагы мәзәкләрен искә төшереп көләләр.* И. Гази. || Уен. [*Вәли:*] *Шәкертләр күңел ачу кичәсе дигән мәзәк ясыйлар икән.* Т. Гыйззәт.

4. *с. мәгъ.* Уенчак, шаян. [*Рәхимә елмаеп:*] *Сез икегез дә мәзәк кеше, ахры.* А. Әхмәт. || Гаҗәп, сәер, ят.— *Мәзәгрәк холыклы кеше булган ул, әтәчләр яраткан.* Г. Әпсәләмов. || *рәв. мәгъ.* Кызык, көлке. *Габдулланың яучы Биби булып укуы һәм кылануы аеруча мәзәк тоелды.* Ә. Фәйзи.

◇ **Мәзәк ясау** — кызык ясау, шаяру, уйнау; күнел ачу.— *Син, Шәмсекамал белән дә мәзәк кенә ясамакчы булган идем, дидең!* А. Шамов.

МӘЗӘКЛЕ *с.* Шаян, көлке, кызыклы, уенчак. *Кунакларның килгәне берсе берәр төрле мәзәкле сүз белән каршы алына.* Ш. Камал. [*Әкиятләрнең*] *коточкыч куркынычлысы да һәм шаркылдап көләрлек мәзәклесе дә була.* М. Шабай.

МӘЗӘКСЕНҮ *ф. сөйл.* Гаҗәпләнү, сәерсенү, аптырап калу. *Бухгалтерлары, ни әйтергә белмичә, мәзәксенеп калдылар.* С. Рафиков.

МӘЗӘКЧЕ *и.* **1.** Шаян сөйләргә яратучы, шаян, шук кеше, көр күңелле кеше. *Яшьлегеңдә мәзәкче булсаң, картлыгыңда такмакчы булырсың.* Мәкаль. *Иренчәк игенчедән илгәзәк мәзәкче узган.* Мәкаль.

2. Цирк та: комик.

МӘЗӘКЧЕЛ *с. к.* мәзәкчән. *Һәрчак шат күңелле, мәзәкчел һәм мәзәкчеллеге аркасында „артист“ дип йөртелгән Дудка фамилияле солдат мәкерле генә елмаеп* [*куйды*]. Каз. утл.

МӘЗӘКЧЕЛЕК *и.* Мәзәкче кешегә хас сыйфатлар. *Ротада мәзәкчелеге белән танылган яшь солдат Андрей Гаврилов --- шаян күзләрен солдатлар өстеннән йөгертте.* И. Туктар.

МӘЗӘКЧӘН *с.* Мәзәк сөйләргә яратучан, шаян, шук. *Нәби—һаман да шул ук мәзәкчән кеше.* Р. Төхфәтуллин.

МӘЗҺӘБ *и. иск.* **1.** Гыйлемдә, фәлсәфәдә, дөньяга карашта тоткан юл, юнәлеш. *Менә шушы бөтен дөньяга „байронизм“ мәзһәбен тудырган --- кешенең кулга алырлык берәр әсәре безнең татар теленә күчерелгәне бар идеме?* Г. Тукай.

2. *дини.* Секта, дин. *Мәзһәб башлыгы.* □ *Нинди генә диндә, нинди генә мәзһәбтә яки кайсы гына милләттә булмасын, һәркем бер иркен сулыш алып, гажәпсенеп, уңга-сулга карый башлады.* Ш. Мөхәммәдев.

МӘЗҺӘБЧЕ *и. иск.* Секта члены, сектант.

МӘЙ *и. сөйл.* Аракы, исерткеч. *Чәй кызулыгы җитмәсә, Мәйләр әчәрбез әле.* Җыр.

МӘЙДАН *и.* **1.** Шәһәр яки авыл эчендә биналар, корылмалар булмаган зур гына ачык, буш урын. *Казандагы Ирек мәйданы.* □ *Кремль кыңгыраулары ның вәкарь чыңлавын һәрвакыт дулкынланып тыңлыйм, шул чак Кызыл мәйдан һәм Ленин мавзолее күз алдына килеп баса торган иде.* Г. Бәширов.

2. Берәр нәрсә өчен хәзерләнгән яки берәр нәрсә биләп торган җир пространствосы.— *Болынлык аз, печән кыш чыгарга да җитми, бәрәңге, тамыразык мәйданын арттыруны идарә алдына куярга.* Ә. Еники. *Карп Васильевич белән Газинур делянканың менә шушы үзәк мәйданында әшиләр.* Г. Әпсәләмов.

Авылның нәкъ уртасында базар өчен дип хәзерләнгән бик зур мәйдан бар. Г. Ибраһимов.

3. Күмәк төстә күнел ачу уеннары һ. б. ш. була торган урын. *Сабан туена мәйдан Казанга якынрак җиргә корылган.* □ *Алар Ачасыр юлында мәйдан булачак чирәмлеккә менеп киттеләр.* Соц. Тат. || Шундый урында үткәрелә торган уеннар. *Бер-ике йорттан кешеләр чыгып Габденнасыйрны кунаклары белән керергә кыстасалар да, тиздән мәйдан башлануны сылтау итеп, ул кермәде.* М. Гали.

4. *мат.* Яссылыкта яки өлектә яткан геометрик фигураларны характерлаучы төп математик зурлыкларның берсе. *Озынчыкның мәйданын билгеләү. Өчпочмакның мәйданы.*

5. Нинди дә булса хәл, вакыйга булган урын. *Сугыш мәйданы.*

6. *күч.* Нинди дә булса эшчәнлек өлкәсе. *Ярыш мәйданы.* □ [*Ш. Камал*] *әдәбият мәйданына Россиядә 1905 елгы революция дулкыннары бастырылган һәм иң каты кара реакция хөкем сөргән чорда килде.* М. Җәлил. || *күч.* Нәрсәгә дә булса мөмкинлекләр, юл. *Мәйдан ачылды яңа көчләргә.* М. Гафури. *Безнең илебездә иҗат мәйданы киң.* Каз. утл.

◇ **Мәйдан тоту (алу)** — 1) ярышта җиңү.— *Шул ябага тае белән мәйдан алсын!* Н. Исәнбәт. *Мәйдан тоткан, ат уйнаткан чакларын искә төшерү Мортазинга юеш тәнгә электр тогы тигән кебек тәэсир итте.* Г. Әпсәләмов; 2) өстен чыгу, җиңү, өстенлек алу.— *Килер бер заман, хакыйкать мәйдан алып, дөньяга гадәләт нуры чәчелер.* Ф. Әмирхан. **Мәйданга кую** — нәрсәне дә булса массага тәкъдим итү, көн тәртибенә кую. *Көнчыгышны һәм иҗтимагый тарих баскычларының төрләрен өйрәнүне мәйданга кую.* **Мәйданга чыгу (килү)** — 1) халыкка таралу, билгеле булу. *Бер атна да үтмәде, бу хәбәрнең раслыгы мәйданга чыгып, газеталарга да таралды.* Ш. Мөхәммәдев; 2) дөньяга чыгу, матбугатка чыгу, басылып чыгу. *Якын арада тарихи ике зур том әсәр[ләр] мәйданга чыг[ачак].* Г. Нигъмәти; 3) нинди дә булса өлкәдә эшли башлау, эшчәнлек белән танылу. *Узенең башлангыч әсәрләрендә үк инде [Г. Камал], әхлак сатучы булудан бигрәк, тормыш тәнкыйтьчесе булып мәйданга чыга.* М. Гали.

МӘЙДАНЧЫК *и.* Берәр максат белән нәрсә өчендер файдаланырлык итеп хәзерләнгән урын; тигез җир, зур булмаган мәйдан. *Спорт мәйданчыгы.* || Нинди дә булса эш башкарыла торган урын. *Каланчаның күзәтү мәйданчыгында кеше сыярлык итеп ясалган озынча скамья бар.* Г. Гобәй.

МӘЙМҮН I *и. иск.* Маймыл. *Мәймүнгә күзлекләр файда итмәде, Адәмнәргә бу күзлекләр яраса да.* М. Гафури.

МӘЙМҮН II *с. иск.* Шат, бәхетле. *Мин, Мәймүнә дигәндә, мәймүн булам, Туңган дәрья ташыганда Сәйхун [Сыр-Дарья елгасының борынгы исеме] булам.* Ш. Бабич.

МӘЙТӘМ *кер. сүз. сөйл.* Мин әйтәм, **дим.**— *Кешенең кабар ризыгы бетмәгән булса, Гандәлип түти, ис итмәгәндә килә дә чыга бит, мәйтәм.* Ш. Камал.— *Вакытыңны бушка уздырасың, мәйтәм, җәй үткәч, җиләккә бармыйлар бит, улым.* Д. Аппакова.

МӘЙХАНӘ *и.* **1.** *иск.* Исерткеч эчемлекләр сатыла торган йорт, кабак. *Күренеп тора каласы, Тау башында ханәсе — Чәйханәме, мәйханәме, Чыңлый савыт-сабасы.* Н. Исәнбәт. *Тулган шәһәр Чәйханәсе, мәйханәсе; Җөмлә татар бай баласы, Бән егъламый кем егъласын.* Г. Тукай.

2. *сөйл.* Ыгы-зыгы, шау-шу, буталыш. *Звонок [өй эченнән ишетелгән] мәйханәне туктатты.* Б. Камалов.

◇ **Мәйханә килү** — ыгы-зыгы килү, буталу. [*Кызым*] *бик бала ярата, шуңа күрә мин эштә чагында көне буе бала-чага белән мәйханә килеп йөри.* А. Расих. *Бөрһан белән Мәдинә, --- мәйханә килеп, эш турында бәхәсләшәләр иде.* М. Хәсәнов.

МӘК *и. бот.* **1.** Матур әре чәчәкле, эченә вак орлык тулган тартмачыклар формасында җимеш бирә торган үсемлек. *Чәчәк ата кызыл мәк, Мәккә куна күбәләк.* Ә. Ерикәй. *Күпьеллык мәкне декоратив үсемлек итеп үстерәләр.* Йорт эшләре.

2. Шул үсемлекнең орлыгы. *Мәк сипкән ак булка.* || Шул орлыктан хәзерләнгән. *Мәк пирогы. Мәк мае.*

МӘКАЛЬ *и.* Тормыштагы төрле гыйбрәтле күренешләрне гомумиләштереп, тапкыр әйтелгән тәгъбир, фраза. *Сүз күрке мәкаль белән.* Мәкаль.

МӘКАЛЬЛӘШҮ *ф.* Мәкаль булып кулланыла башлау, аерым фразаларның гыйбрәтле мәкаль булып әверелүе. *Мәкальләшкән сүзләр.*

МӘКАЛЬЧЕ *и.* Мәкальләр җыючы.

МӘКАЛӘ *и.* Журналда, җыентыкта яки газетада фәнни яисә публицистик стильдә язылган зур булмаган күләмдәге инша. *Баш мәкалә. Тәнкыйть мәкаләсе.* □ [*Журналда*] *революцион рухта язылган мәкаләләрне еш очратырга туры килә.* М. Гали.

МӘКАМ *и. иск. кит.* **1.** Дәрәҗә, тоткан урын. *Бүлмәмә кереп ятуны хәл вә мәкамгә тиешле күрдем.* Ф. Әмирхан.

2. Көйле тавыш, көйле тон. *Бу — бик тиз, кызу, ләкин музыкалы яңгыратып, Шәйморза мәкаме белән укучы иде.* Г. Ибраһимов. *Өй хуҗасының бер озынайтып, бер кыскартып, моңлы гына мәкам белән иртә намазы укыганлыгы ишетелеп тора.* Ш. Камал.

МӘКЕР *и.* Астыртын явызлык, астыртын усаллык; астыртын явыз эш яки уй. *Мин сүзгә кушылмыйча, әлеге агач башмаклы кыз һәм аның җинаяте, мәкере турында уйлап, Газизовка караштырып утыра идем.* А. Шамов. *Мәлгунь дошманның мәкерен каян белеп бетерәсең.* М. Шабай.

◇ **Мәкер саклау** — ачу саклау, үч тоту. [*Дминов*] *күршедә торган земский начальнигының аңа карщы мәкер саклаганын да искә алды.* Х. Кәрим.

МӘКЕРЛЕ *с.* Эчкерле, астыртын усал, астыртын явыз. *Аның кесәсендә револьверы булган һәм биредә ул мәкерле планын корып утырган.* Р. Ишморат. *Уйлана торгач, Хисаминың башында бер мәкерле фикер өлгереп җитлеккән иде.* Г. Минский.

МӘКЕРЛЕК *и.* Астыртынлык, астыртын усаллык, астыртын явызлык, эчкерлелек. *Ниһаять, Зөфәрдә коммерсант усаллыгы һәм мәкерлеге уянды.* Ә. Еники.

◇ **Мәкерлек итү** — кемгә дә булса астыртын явызлык эшләү. *Төп темага параллель рәвештә әсәрдә Булат белән Рәйханәнең мәхәббәте һәм управляющий Аблайның, арага кереп, мәкерлек итүе бирелгән.* М. Җәлил.

МӘКЕРЛЕЛӘНҮ *ф.* Эчкерлеләнү, астыртынлану; астыртын усаллык, явызлык күрсәтү.

МӘКЛЕ *с.* Мәк катнаштырылган, мәк салынган, өстенә мәк сибелгән. *Мәкле булка.*

МӘКЛӘҮ *ф.* Мәк катнаштыру, мәк салу, мәк сибү. *Пирог өстен мәклә.*

МӘКТӘП *и.* **1.** Яшь буынга гомуми белем һәм тәрбия бирә торган уку йорты. *Төрле-төрле гыйлем, һөнәр белмәк кирәк, һөнәр, гыйлем мәктәбенә кермәк кирәк. Мич башына гыйлемлекләр килеп кермәс, Гыйлем өчен аһ-ваһ итеп йөрмәк кирәк.* Г. Камал.

Габделкаюм авыл мәктәбендә өч кыш укыды. М. Гали. || Шул учреждение урнашкан бина. *Ул алты почмаклы зур мәктәп салдырып китте.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр белгечлек буенча махсус уку йорты. *Балет мәктәбе. Трактористлар мәктәбе. Хәрби мәктәп.* □ *Айсылу белән Хәйдарнең димләве буенча, укырга алуларын үтенеп, [Зиннәтнең] музыка мәктәбенә гариза җибәрүенә дә бер айдан артып киткән иде.* Г. Бәширов.

3. Уку-укыту учреждениеләре, уку-укыту системасы. *Мәктәпне дуннан аеру.*

4. Тәҗрибә туплау; тупланган тәҗрибә, алган белем. *Тормыш мәктәбе үтү.* || Шундый тәҗрибәне, шундый белемне бирә торган нәрсә. *Казанда көннәнкөн колач җәя барган марксистик түгәрәкләр революционерлар өчен җитди мәктәп булды.* Каз. утл. *Әлбәттә, пролетариатның революцион көрәш мәктәбен үтмәгән [М. Гафури] өчен пролетариат революцион позициясенә җиңел генә басу читен иде.* М. Җәлил.

5. Нәрсәне дә булса өйрәнү өчен практик алымнар системасы; метод. *Химикларның Арбузов мәктәбе.*

6. Әдәбият, сәнгать, фән, иҗтимагый-политик фикер өлкәсендәге юнәлеш, агым. *Татар әдәбиятында реализм мәктәбе.* □ *Ленин мәктәбендә тәрбияләнгән, Ленин идеяләренә бөтен гомере буена турылыклы М. И. Калинин дәүләт эшен пропаганда эшеннән беркайчан да аермады.* Соц. Тат.

МӘКТӘПКӘ'ЧӘ *с.* Мәктәпкә кадәрге. *Мәктәпкәчә тәрбия эшләре. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар.*

МӘКТӘПТӘШ *и.* Кем белән дә булса бер мәктәптә укучы.

МӘКТҮП *и. иск.* Хат. *Уннаган мәктүпләремә бер җавабыңны кызганмассың дип өмет итәм.* Г. Ибраһимов. *Үземнең мәктәп аркадашымнан мәктүп алдым.* Г. Газиз.

МӘЛ *и. сөйл.* Чак, вакыт. *Бүген уйнап-көлүдән тыйма, зинһар, --- Тыя күрмә, уен уйнар мәлендә.* Дәрдмәнд. *Камил белән Санияҗә беренче мәлдә бу өч бүлмәле квартира клуб бинасы кадәр булып күренде.* М. Әмир.— *Ай, канатым, Айсылу, кайсы мәлне дүрт аяклы хайван да сөртенә.* Г. Бәширов. || Кайбер сыйфат фигыльләре белән бергә килгәндә; „шунда ук, кичектермичә, берәр нәрсәне эшләү белән" кебек мәгънәләр аңлата. *Кайткан мәлгә. Кергән мәлгә.* □ *Килгән мәлгә ул таудан бер туктамый биш-алты мәртәбә шугач, үзендә нинди дер талчыгу сизде.* А. Алиш.

МӘЛГУНЬ *с. иск.* Начар, юньсез; әшәке. *Бу коридор, бу бүлмәнең бүгенге кыяфәте үк мине инде шушындый бер мәлгунь сүз ишетергә хәзерләп куйган [иде].* Ф. Әмирхан. || Мордар, явыз, кара. *[Безне] мәлгунь көчләр каушата алмас.* М. Фәйзи. || Ачулану, тиргәү, сукрану сүзе: шайтан.— *Ичмасам, күңел өчен генә дә „барып чыгыгыз" дип әйтми бит, мәлгунь!* Ш. Камал.

МӘЛГУНЬЛЕК *и. иск.* Мәлгунь кешегә хас сыйфатлар. *Байның малы арткан саен, явызлыгы, залимлеге, мәлгунълеге бетмәде, һәмишә арта барды.* Ш. Мөхәммәдев.

МӘЛЛЕ *рәв. диал. к.* вакытлы *(2 мәгъ.).*

МӘЛСЕЗ *рәв.* Вакытсыз, вакыты җитмичә. *Мәлсез чәчәк ярылмас.* Әйтем.

МӘЛӘК *и. иск.* 1. *к.* фәрештә. *Куанды ил, канат какты мәләкләр.* Дәрдмәнд. *Куш мәләкләргә, җиһаныңны тазартсыннар иде.* Г. Тукай.

2. *шигъ.* Бик чибәр кыз, сөйгән яр турында. *Мәләгемне күрми калган көннәрне авыру булам.* М. Гафури.

МӘЛҖЕРЕК *с.* Мәлҗерәгән. *Төнлә исерек, көндез мәлҗерек.* Әйтем.

МӘЛҖЕРӘЮ *ф. к.* мәлҗерәү.

МӘЛҖЕРӘҮ *ф.* 1. Төрле сәбәптән бик хәлсезләнеп, үзеңне йөртә яки гәүдәңне, буыннарыңны тота алмас хәлгә төшү. *[Аракы эчеп исергән Госман:] Мәлҗерәдем, мәлҗерәдем, эштән чыктым.* Ш. Камал.

2. Артык йомшап, бөтенләй ихтыярсыз булып, җебеп калу. *Чанасы булмауга карап, Биктимер шулай ук мәлҗерәргә һич тә уйламый.* Ф. Хөсни. *[Сәгыйть] Миңлегөл алдында да бер сүз әйтә алмыйча мәлҗерәп төште.* Р. Төхфәтуллин.

МӘЛҖҮ *ф. к.* мәлҗерәү.— *Авызымны пешерә-пешерә [чәй] әчтем, әчемә җылы керде. Шуннан инде бөтенләй мәлҗедем.* Каз. утл.

МӘМИ *и.* 1. Балалар телендә: тәмле нәрсә, тәмле азык; гомумән ашамлык. *Аны, бәлкем, өендә „әби, тиз кайт, мәми алып кайт", — дип, кечкенә кызы көтеп калгандыр.* Г. Гобәй. *Әнкәй, мәми пешереп, әткәйне эштән көтә.* Җыр.

2. *куч. сөйл. кимс.* Булдыксыз кешегә карата „җебегән, пешмәгән" мәгънәсендә әйтелә.— *Кайбер мәми егетләргә борычлап-суганлап әләктергән ул [хикәядә].* Г. Мөхәммәтшин.

◇ **Мәми авыз** — җебегән, булдыксыз кеше.— *Әллә шул мәми авызны яратып торган буласыңмы?* Г. Камал. **Мәми авызлану** — булдыксызлану, җебеп тору. **Мәми авызлык** — булдыксызлык, җебегәнлек. *[Муса] бая гына мәми авызлык күрсәтүе өчен үзен әрләп куйды.* Ш. Маннур.

МӘМИЛЕК *и. кимс.* Мәми авыз булу.

МӘМИЛӘНҮ *ф. сөйл.* Булдыксызлану; батырчылыгы, кыюлыгы җитмәү. || *рәв. мәгъ.* **мәмиләнеп.** Кыюсызланып, җебеп. *[Әптерахман] куркак куян бер, Кеше белән мәмиләнеп, Борынын тартып сөйләшә.* М. Җәлил. || Капризлану.

МӘМЛӘКӘТ *и. иск.* Ил, дәүләт. *[Патша:] Минем өчен --- әлегә кадәр бер патша да кимәгән, бер мәмләкәт тә белмәгән, бер патшаның да күзе күрмәгән, иң кыйммәтле, иң матур, иң яхшы таҗ ясагыз.* А. Алиш.— *Минем кайсы кабиләдән, кайсы мәмләкәттән булуым сезгә кирәк түгел.* Ш. Усманов.

МӘМНҮН *хәб. сүз. иск.* Канәгать, риза. *Җәй эссесендә шәһәрдә торып туйган Тукай бу чакырудан мәмнүн иде.* Ф. Әмирхан. *Абыстай үзе киленнән --- бик мәмнүн, аны бик ярата, үз балам итәрмен, дип, аркасыннан кагып йөртә.* Г. Ибраһимов.

МӘМӘЧ *и. диал.* Агач кайрысы астындагы сыекча, су. *Яр буендагы нәзек талларның кайрылары астына әчкелтем мәмәч йөгерер.* И. Гази.

МӘН I *и. иск.* Берәү; зат, шәхес, кеше. *Бер мән төшендә үзенең министр яки губернатор булганын күрсә, гомере кыска булгай.* Ш. Мөхәммәдев.

МӘН II *и. сөйл.* Мәгънә, рәт, җай. *Бер дә мин бу эшнең мәнен табалмыйм.* М. Җәлил. *Олы кешене олы итеп, зурлап, хөрмәтләп каршы алу мәнен белсәләр ярый ла.* Ш. Хөсәенов. *Кыз мәнен кем белгән, кыз куенында ятмагач.* Мәкаль.

МӘНДИ: Мәнди анасы да белә — „Һәркем белә, һәркемгә билгеле" мәгънәсендә.— *Бай кызларының офицерларча кыланганын Мәнди анасы да белә бит!* Ф. Әмирхан.

МӘНЗУМ *с. иск. кит.* Тезмә, тезмәле, үлчәүле; көйле. *„Таң йолдызы"ннан бер мәнзум кыйсса күчердек.* Г. Тукай.

МӘНЗУМӘ *и. иск. кит.* Дастан.

МӘНЛЕ *с.* Мән белә торган; тәртипле, рәтле.— *Кодагый бик мәнле, бик һәйбәт кеше, эшнең җаен*

бик белә торган кеше. Г. Камал. *Мәнле шул шайтан, — дип дустанә рәвештә уйлап алды Ифрат (Иван Иванович турында), — кеше күңелен таба белә.* А. Расих.

МӘНЛЕЛЕК *и.* Мәнле булу, мән (II) белүчелек.

МӘНСЕЗ *с. сөйл.* Мәгънәсез, юньсез, мән (II), рәт белми торган. *Мәнсез була икейөзле кешеләр.* З. Нури. [*Гөлсем апа:*] *Мәнсез дә инде мин, каушавым белән кичә исемә килмәгән.* Г. Гобәй.

МӘНСЕЗЛЕК *и. сөйл.* Мәнсез булу, мәгънәсезлек, юньсезлек. [*Василий*] *гаҗәеп бер мәнсезлек белән авызын зур-зур ачып иснәргә тотынды.* Ә. Еники.

МӘНФӘГАТЬ *и. иск.* Файда, игелек. [*Искәндәр Галимәбануга:*] *Белмисең син! Төшенмисең. Мәнфәгать дигән нәрсә бар лабаса!* М. Фәйзи. *Чабатаң берлә, нинди мәнфәгать бар соң, әдәп таптап?* Г. Тукай. || Интерес, файда. *Үз мәнфәгатьләре белән сукырайган бер төркем кешеләр табигатьне талауларын сизми калалар.* А. Гыйләҗев. [*Бикмурзин*] *ул карак. Чөнки ул кеп-кечкенә башы белән әшче мәнфәгатен саткан кеше.* А. Алиш.

МӘРГӘН *и.* 1. Төз атучы. *Басма өстендә бала үрдәк, Мәргән булсаң ат инде!* М. Фәйзи. || Снайпер.

2. *сир.* Аучы. *Кулы озын — мәргән булыр.* Мәкаль.

МӘРГӘНЛЕК *и. сир.* Мәргән булу.

МӘРКӘЗ *и. кит.* 1. Нәрсәнең дә булса уртасы, үзәге. *Кайчандыр бакчадагы хәятның [тормышның] мәркәзе булып торган бу беседка бүген инде әченә керәлмәслек булып җимерелгән.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Нәрсәнең дә булса уртасы, үзәге саналган. *Калькуттаның мәркәз өлеше хәзерге заман Европа шәһәренә охшаган.* Каз. утл. *Икенче көнне авылның мәркәз урамы, кара болыт кебек, күп халык белән капланган иде.* Х. Кәрим.

2. Идарә үзәге, башкала. *Мәркәз белән бәйләнеш юлын нинди генә бәһа белән булса да сакларга карар бирелгән.* Ш. Усманов.

3. *күч.* Нинди дә булса өлкәдә төп, үзәк нәрсә. *Бу көн сүзнең мәркәзе [Зыяның солдатка алыну ихтималы] булачак иде һәм булды да.* Г. Ибраһимов. *Әйләнер дөнья һаман да, Булмас аңа берни дә! Уйлыйсыңмы дөньяның син Мәркәзе дип мин генә!* Н. Исәнбәт.

МӘРКӘЗЛӘШТЕРҮ *ф. кит.* Үзәкләштерү; берләштерү. [*„Тирән тамырлар"ның] сюжеты катлаулы һәм композициясе бер ноктага җыю, мәркәзләштерү нигезендә төзелгән.* Г. Нигъмәти.

МӘРКӘЗЛӘШҮ *ф. кит.* Үзәкләшү.

МӘРМӘР *и.* Скульптура һәм архитектура эшләрендә кулланыла торган төрле төстәге кыйммәтле кристаллик тау токымы; *русчасы:* мрамор. *Безнең уң ягыбызда, ниндидер коймалар арасына ал мәрмәрдән салынган сарай күренә.* Ф. Әмирхан. *Мең ел яңгыр яуса да, мәрмәр ташка су үтмәс.* Мәкаль. || *с. мәгъ.* Мәрмәрдән ясалган. *Бакчаның уртасында мәрмәр бала скульптурасы курай аркылы югарыга су пошкыртып тора.* Ш. Камал. *Ә директор аны каршылады, Мәрмәр балконыннан елмаеп.* М. Җәлил.

◇ **Мәрмәр теш** — ап-ак матур тешләр турында.

МӘРСИН *и.* Кара уылдык бирә торган кыйммәтле балык; *русчасы:* осетр.

МӘРСИЯ *и. кит.* Үлгән кешенең яхшы сыйфатларын күрсәтеп язылган сүз яки шигырь, әлегия. *Мәрсияләр һәм кайбер башка төр шигырьләр элегик лириканың аерым үрнәкләре булып торалар.* Каз. утл. *Тукай Заһир Бигиев, Шиһап Мәрҗани, Хөсәен Ямашев хезмәтләрен җырлаган мәрсияләр яза.* Х. Госман.

МӘРТ *и.* Тышкы тәэсирләргә бернинди реакция булмау һәм тулы хәрәкәтсезлек белән характерлана торган йокыга охшаш авыру хәл; летаргия.

◇ **Мәрткә китү** — 1) *мед.* летаргик йокыга талу. *Шулай да аның белән әллә ни булды: ул тәмам үз әченә йотылды һәм бөтенләй телдән калды, — әйтерсең, мәрткә китте.* Ә. Еники. 2) тирән йокыга талу.— *Сул кабыргага әйләнеп яттым да, мендәргә башны төртү белән мәрткә киттем дә бардым.* Г. Ахунов. **Мәрттән кайту** — летаргик йокыдан уяну.

МӘРТӘБӘ I *рәв. к.* тапкыр (1 мәгъ.). *Алар икәү авылның караңгы бер җирендә беренче мәртәбә авылның якын киләчәге хакында пионер җыры җырладылар.* Һ. Такташ.

МӘРТӘБӘ II *и.* 1. Дәрәҗә, исем, абруй. *Һәр олуглар эшләгәнлектән олуглыклар таба, Уйнады дип, бирмиләр ушбу җиһанда мәртәбә.* Г. Тукай. [*Бөтен халыклар*] *җиңеп дошманны, түгеп канны, Дошман өстенә кубарып туфанны, Үзенә ирлек, халкына ирек, Иленә шөһрәт, мәртәбә алды.* Г. Камал. || Өстенлек; мактаулы эш.— *Аның эшкә уңган булып чыгуы мәртәбә мәртәбәлеккә дә, тирәсендә егет-җиләннең болай тырышып бөтерелүе генә әчемне пошыра.* Ф. Хөсни.

2. Кемнең яки нәрсәнең дә булса хәле, халәтенең интенсивлыгы турында сөйләгәндә кулланыла: хәл, дәрәҗә.— *Ачу вә әрнүемнән әллә ниләрне өзгәләп ташларлык мәртәбәгә җитәм.* Г. Ибраһимов.

◇ **Мәртәбә иясе** — абруйлы кеше, бик хөрмәт ителә торган кеше. *Җәләү мулла угылларын да зур мәртәбә иясе, бай, иркен тормышлы ... [кешеләр] итеп күрәсе килә.* Г. Нигъмәти. **Мәртәбәгә ирешү (менү)** — югары дәрәҗә алу. *Галиәскәр нинди зур мәртәбәгә менде.* Ә. Фәйзи. **Мәртәбәгә күтәрү** — зурлау, олылау.

МӘРТӘБӘЛЕ *с. сөйл.* 1. Дәрәҗәле, абруйлы. *Мәртәбәле кеше.* || Мәртәбә (II, 1 мәгъ.) китерә торган. *Мәртәбәле эш.*

2. Рухи яктан бөек; югары, гали. [*Зыя:*] *Татарның асыл табигате бөек, җаны мәртәбәле, йөрәге бик хәссас.* Г. Ибраһимов.

МӘРХӘМӘТ *и.* Шәфкать, яхшылык, игелек.— *Дөресен сөйлә, ялганласаң, миннән мәрхәмәт көтмә.* К. Тинчурин.— *Бу алтын игеннәр табигать мәрхәмәте буенча гына үсмәгән бит, аларны кеше үстергән.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Мәрхәмәт итү (кылу, күрсәтү)** — яхшылык итү, игелек итү, кызгану, аяу, ярдәм кулын сузу, мәрхәмәтле булу. *Бичара картның күзләреннән мөлдерәп аккан яшьләрен күрегез, сез дә кызганыр вә мәрхәмәт итәр идегез.* Ш. Мөхәммәдев.— *Кабахәт оккупантларга мәрхәмәт күрсәтмәгез, - - - кырыгыз, юк итегез.* А. Шамов.

МӘРХӘМӘТЛЕ *с.* Шәфкатьле, игелекле, кызганучан, итагатьле. *Әнкәем кебек мәрхәмәтле миңа, Изге миңа җирнең туфрагы.* Ә. Ерикәй. *Сөйгәнемнең нурлы һәм мәрхәмәтле күзләренә текәлеп карап торган чагымда да кәккүк кат-кат кычкырып куйды.* Ә. Еники.

МӘРХӘМӘТЛЕК *и.* Мәрхәмәт, шәфкать, яхшылык. *Мәрхәмәтлек күрсәтүче.*

МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК *и.* Мәрхәмәтле кешегә хас сыйфатлар.

МӘРХӘМӘТЛЕЛӘНҮ *ф.* Шәфкатьле, игелекле булып китү, йомшак күңеллеләнү. *Туганым кешегә карата йомшак күңелле булып, мәрхәмәтлеләнеп киткәндәй тоела.* Каз. утл.

МӘРХӘМӘТСЕЗ *с.* 1. Кызганмый торган, шәфкатьсез, каты холыклы, кансыз. *Мәрхәмәтсез тәнәремә*

һичбер теләгем бармады. Һ. Такташ. || Шундый характерны сиздерә торган. *Мәрхәмәтсез күзләр. Мәрхәмәтсез кыяфәт.* || *күч.* Шәфкатьсез. *Бу иртәнең җылы тынлыгы --- якында гына мәрхәмәтсез сугыш, кан һәм үлемнең барлыгын онытып торырга мәҗбүр итә.* Ә. Еники.

2. Түзә алмаслык авыр. *Зарлы иде сезнең көнегез, Мәрхәмәтсез иде төнегез.* Ә. Ерикәй.

МӘРХӘМӘТСЕЗЛЕК *и.* Мәрхәмәтсез булу сыйфаты. *Иске тәртипләрне бөтен мәрхәмәтсезлеге белән кайтарырга омтылучы көчләр [Кавказ, Дон, Себер якларына] ташланалар.* К. Нәҗми.

МӘРХҮМ *и.* Үлгән ир кеше. [*Ает.*] *Атаң мәрхүм, әле мулла булып торып та, муллалыгын ташлап, шәһәргә күчәргә кызыгып йөри торган иде.* М. Гали. *Мәрхүм кече күңелле, бик яхшы кеше иде.* К. Тинчурин.

МӘРХҮМӘ *и.* Үлгән хатын-кыз.— *Авыр туфрагы салмаклы булсын мәрхүмәнең!* А. Шамов.

МӘРӘ *и. диал. к.* әйләнә. [*Хаҗи*], *көлемсерәп, ике имән бармагы белән ашъяулык өстендә алга таба ярым түгәрәк мәрә сызды.* Ш. Камал.

МӘРҖӘН *и.* **1.** *зоол.* Диңгез кыяларында хәрәкәтсез төркемнәр булып укмашып яши торган диңгез хайваны. **2.** Шул хайваннарның кайбер төрләре скелетындагы известь утырмаларында барлыкка килгән һәм тиешле эшкәртүләрдән соң бизәү әйбере итеп файдаланыла торган ачык кызыл, алсу яки ак төстәге кыйммәтле таш. *Мин күңелемнең энҗе, мәрҗән төсле Иң кыйммәтле яшьлек серләрен Беркемгә дә түгел, Бары Димгә, Аның ярларына сөйләдем.* М. Җәлил. || Шул ташның кечкенә бөртеге. *Әлфия, диван кырыена сөялер-сөялмәс, вак мәрҗәннән тезелгән беләзеген шудыргалап, бер стенага, бер беләзегенә карый-карый сөйли.* Г. Бәширов. || *диал.* Шул таштан яки нинди дә булса башка материалдан ясалган йомры яисә башка төрле формадагы вак бөртекләрдән тезелгән, муенга тага торган бизәнү әйбере. *Өстәл өсләрендә ак мәрҗәннәр, Алып бәйлә, бәгърем, муеныңа.* Җыр.

Мәрҗән агачы *диал.* — яшькелт сары чәчәк атып, миләшкә охшаш кызыл яки кара җимеш бирә торган декоратив куак үсемлек; *русчасы:* бузина красная. *Җимеш бакчасына аяк бастырырга ярамаган мәрҗән агачы да каралтыларга якынрак рәшәткә буенда рәхәтләнеп үсеп утыра иде.* Ә. Еники.

МӘРҖӘНЛЕ *с.* Мәрҗән белән бизәлгән.

МӘСГУД *с. иск. кит.* Бәхетле, игелекле. *Инде мин шул дәрәҗә мәсгуд бер хәлфәмен.* М. Җәлил.

МӘСГУДИЯТ *и. иск. кит.* Бәхетлелек, бәхетле булу, рәхәтлек. *Адәмнең бәхете, мәсгудияте өчен гыйлем, фәлсәфә, мәдәният юлын күрсәтүче галимнәр, рәхим итеп --- килегез!* Г. Ибраһимов.

МӘСЛИХӘТ *и. кит.* **1.** Киңәш.— *Һилал иптәш, бер мәслихәт бар иде сиңа.* К. Тинчурин. *Кешенең күплеге эшкә ярар, мәслихәткә ярамас.* Мәкаль.

2. *хәб. функ.* Яхшы эш, акылга сыярлык эш, урынлы эш.— *Шушындый кызу эш вакытында шәһәргә барып йөрүләрне мәслихәт дип әйтеп булмый.* Ш. Камал. *Мәслихәт, бик мәслихәт, — дигән булды хәзрәт.* Г. Минский.

Мәслихәт булу — яхшы булу, уңышлы булу, урынлы булу.— *Гаилә эчендәге гаугаларны үзара бетерү мәслихәт булыр.* Т. Гыйззәт. **Мәслихәт күрү (табу)** — яхшы дип табу, хуп күрү, нәрсә турында булса да килешү.— *Сеңлебез барырга риза булса, без мәслихәт күрсәк — сезгә хәбәр биреп тә тормас идек.* Ш. Камал. **Мәслихәт кылу (кылышу)** — киңәшү, киңәшләшү.— *Мәслихәт кылышып эшләргә кирәк иде, әфәндем!* Ә. Фәйзи. **Мәслихәт мәҗлесе (җыелышы)** *иск. кит.* — киңәшмә.— *Мыек Шәмсетдин үзе кузгалган икән, бу инде килде-китте утырыш кына түгел, зур мәслихәт җыелышы булырга охшый.* Г. Бәширов.

МӘСЛИХӘТЛЕ *с. кит.* Киңәшле, киңәшеп эшләнгән. *Мәслихәтле эш таркалмас.* Мәкаль.

МӘСЛИХӘТЛӘҮ *ф.* **1.** Нәрсәне дә булса мәслихәт табу, мәслихәт күрү, хуп күрү.

2. Киңәшү, киңәшеп раслау. *Утырышның көн тәртибен Суфиянов белән мәслихәтләгәндә, сөйләшүне кайсы юнәлештәрәк алып барырга кирәклеген дә сораган иде.* А. Гыйләҗев.

МӘСЛИХӘТЛӘШҮ *ф.* Киңәшү, киңәшләшү, уртага салып сөйләшү.— *Бик яхшы, барәкалла, барәкалла, үз кеше булгач, әлбәттә, мәслихәтләшми ярамый.* Ш. Камал. *Бәдеркәй дә бу хосуста аның белән мәслихәтләшергә вәгъдә бирде.* З. Һади.

МӘСЛИХӘТЧЕ *и. иск.* **1.** Киңәшче, киңәш бирүче.

2. Киңәш сораучы. *Ни сәбәптәндер, Оракул саташкан, бер мәслихәтче килсә, ялгыш мәслихәт бирә.* Г. Тукай.

МӘСЛӘК *и. кит.* **1.** Караш, дөньяга караш. *Коры иптәшлек түгел фикердә, гали мәсләктә иптәшлек — бу тагы да бөегрәк.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Принцип, максат; тоткан юл, юнәлеш. *Һәр кеше үз мәсләген яхшы күреп, Җәннәттә торган кебек уйнап-көләр.* М. Гафури.

МӘСЛӘКСЕЗ *с. кит.* Принципсыз, үзенең аерым карашы булмаган, аумакай.

МӘСЛӘКТӘШ *и. кит.* Кем белән дә булса бер үк караштагы, фикердәге кеше, фикердәш. *Үзе шикелле үк бер мәсләктәшенең --- сигарка тартып торуы Фәтхулла хәзрәтнең миенә һич сыя алмый иде.* Ф. Әмирхан. *Әгәр [Рәхим] профессорны үз мәсләктәше итә алса, шунда ук аңа эш башларга мөмкинлек бирелачәк.* А. Расих.

МӘСХӘРӘ *и.* Хурлык, мыскыл. *Ул башын, йөрәген кая куярга, бу мәсхәрәдән дөньяның кай төшенә кереп качарга белми, балалар кебек өзгәләнеп, бәргәләнеп елый иде.* Ш. Камал.— *Син минем бу мәсхәрәләремне алтының белән генә түгел, каның белән дә юа алмассың.* Ф. Бурнаш.

Мәсхәрә булу — хурлыкка калу. [*Гайшә:*] *Мин ни эшлим инде? Ил алдында мәсхәрә булам бит!* Г. Ибраһимов. **Мәсхәрә итү (кылу)** — 1) көчләп мыскыллау; 2) мыскыл итү, мыскыл итеп көлү, хурлау.— *Ни өчен генә соң мине болай мәсхәрә иттең?* Р. Ишморат. **Мәсхәрәгә алу** — 1) хурлау, мыскыллау дип аңлау; 2) мыскыллау. [*Кайберәүләр*] *арт яктан санаганда, беренче килде дип тә мәсхәрәгә алалар.* Сов. әд. **Мәсхәрәгә калу (төшү)** — *к.* мәсхәрә булу. [*Аның мәдрәсәгә баргач*] *зур мәсхәрәгә калачагы бар шикелле тоелып китте.* Ф. Әмирхан.

МӘСХӘРӘЛЕ *с.* **1.** Хурлыклы, мыскылланган, кимсетелгән. *Карт хаҗиның татлы хыяллары әнә шулай мәсхәрәле хәлгә калу белән җимереләләр.* Г. Нигъмәти.

2. Мәсхәрәләү белдерә торган, мыскыллы. *Зоя мәсхәрәле елмаю белән безгә карап: „Рәхмәт“, — диде дә, киенү бүлмәсенә чыкты.* М. Әмир.— *Шулай, балакай, — диде начальник мәсхәрәле көлеп, — без бары яхшы кешеләрне генә яхшы итә алабыз.* Г. Гобәй. | *рәв. мәгъ. Карт әрнүле һәм мәсхәрәле елмайды.* А. Шамов.

МӘСХӘРӘЛЕК *и.* Хурлык, мәсхәрә. *Шулар аркасында мин бу көнгә, бу мәсхәрәлеккә калдым.* Г. Камал.

МӘСХӘРӘЛӘҮ *ф.* **1.** Хурлау, хур итү.— *Менә дигән атка шундый тозсыз исем кушып мәсхәрәләмәсәң!* Т. Гыйззәт. || Көчләп мыскыллау. *Ак бандитларның*

мәсхәрәләвеннән котылырга теләп урманда яшеренүче хатыннар күптән таралсалар да, Миңзифа кайтырга ашыкмады. К. Нәҗми.

2. Кимсетү, мыскыллап көлү. [*Рәхим:*] *Әгәр сиңа дуслык мине мәсхәрәләү өчен кирәк икән, туп-туры әйтәм, андый дуслыкның кирәге юк миңа.* Р. Ишморат. *Давыт Йосыфҗанны:— Тфү, байбәтчә, кая килеп тыгыласың, син аңлый торган мәсьәләмени бу! — дип мәсхәрәләде.* Г. Ибраһимов.

МӘСЬӘЛӘ *и.* 1. Хәл ителергә тиешле нәрсә; проблема. *Аграр мәсьәлә.* □ *— Сүзне шәяруга бормa әле, Халикъ абзый, бик әһәмиятле мәсьәлә турында сүз бара.* Ш. Камал. *Нургали азык мәсьәләсен күңеленнән катгый рәвештә чишеп куйган иде.* Ә. Еники. || Тикшерелергә, игътибар ителергә тиешле эш-хәл.— *Иртәгә җыен була, мәсьәләне җыенда халык алдында куярга дигән карар чыгарылды.* Һ. Такташ.

2. *мат.* Кагыйдә буенча билгеле шартлар, юллар белән чишелеп, җавап табылырга тиешле математик характердагы бирем. *Мәсьәләләр җыентыгы.* □ *— Әйтик, шунда имтиханда мәсьәләнең җиңелрәген биреп куйсалар...* Г. Гобәй.

МӘСӘЛ *и.* Кешеләргә, кеше тормышына киная белән хайваннар яки җансыз предметлар турында сөйли торган, күбесенчә вәгазь, үгет-нәсихәт белән тәмамланган кыска шигъри хикәя. [*М. Гафури*] *җанварлар турында язылган мәсәлләре белән хокуксызлыкны тәнкыйтьләде.* М. Җәлил.

МӘСӘЛЧЕ *и.* Мәсәл язучы. *Эзоп та үз фикерләрен ачыктан-ачык әйтә алмый торган „ирекле“ мәсәлче булган.* Ш. Маннур.

МӘ'СӘЛӘН *кер. сүз.* Җөмләдә берәр сүзне, тезисны аңлатканда, нәрсәне дә булса санаганда „мисал итеп“, „мисал өчен“, „мисалга алсак“ дигән мәгънәдә кулланыла. *Хәлимгә берәр шатлык килсә, мәсәлән, дәрестә „5“ алса, Гөлгенә аның өчен яшерен сөенә.* Г. Гобәй. *Мәсәлән, кайчагында чәй эчеп утырганда ул:— Сәгыйдә кызым, калфагыңны алгарак төшер,— дип куя.* Ш. Камал.

МӘСЬҮЛ *с. иск. кит.* 1. Соралган, сораган. *Ул мәсьүл нәрсәләрне поднос белән китереп куйды.* З. Бигиев.

2. Җаваплы. *Мәсьүл редактор.* | *рәв. мәгъ. Һәрбер юлым, һәрбер хисем өчен Мин үземне мәсьүл санадым!* Һ. Такташ.

МӘСЬҮЛИЯТ *и. иск. кит.* 1. *к.* җавап. *(8 мәгъ.). Җаббаров иске гадәт куллануы өчен мәсьүлияткә тартылды.* Ф. Бурнаш.

2. *к.* җаваплылык. *Миңа балчык ташый торган бер арба, бөтен сбруйлары белән бер ат биреп, бөтен мәсьүлиятен үземә тапшырдылар.* М. Гафури.

МӘСЬҮЛИЯТЛЕ *с. иск. кит.* Җаваплы; мөһим. *Мәсьүлиятле урын.* □ [*Татар сәхнә көчләре*] *җыелып, үзенең тарихи мәсьүлиятле һәм шәрәфле эшенә керешә.* Тат. театры.

МӘТЕ *и. диал.* Юеш балчык. *Машина --- көпчәге, котыргандай бер урында әйләнеп, алга-артка мәте чәчүдән башканы белмәде.* Каз. утл.

МӘТЛЕ *с.* Бөтнек орлыгының хуш исле сыгынтысы кушылган. *Медицина, парфюмерия һәм азык промышленностенда кулланыла торган бу кыйммәтле продукт (ментол) әле күптән түгел генә мәтле майдан эшләнә иде.* Соц. Тат. *Утта эретелгән шоколадлы яисә мәтле конфетка бер-ике кашык җылы су яисә сөт кушып, торт өстенә ягу өчен бик яхшы глазурь хәзерләргә мөмкин.* Йорт эшләре.

МӘТРҮШКӘ *и. бот.* Сыек шәмәхә төстәге хуш исле чәчәк ата торган урман үләне, медицина һәм парфюмериядә файдаланыла; *русчасы:* душица. *Мәтрүшкә төнәтмәсе.* □ *Аның борынына юкә, сирень чәчәкләренең нечкә хуш исе килеп бәрелә, аннары мәтрүшкә исе көчәеп киткәндәй була.* Г. Әпсәләмов. *Кипкән мәтрүшкә бик килешә торган иде андый авырган чакта.* И. Гази.

МӘТРҮШКӘЛЕК *и.* Мәтрүшкә үсә торган кыр, алан.

МӘТРҮШКӘЛӘП *рәв.* Мәтрүшкә салып, мәтрүшкә белән. *Мунча бирде ягарга, себеркә бирде чабынырга. „Мунча чыккач мәтрүшкәләп Чәй эчәрсең“ тидия.* Б. Рәхмәт.

МӘТӘКЛӘҮ *ф. диал.* Мәтәлчек ату. *Бер төркем трапецияләрдә упражнениеләр ясыйлар, җирдә мәтәкләләр.* Ш. Камал. *Нишләрен белми, мәтәкли, җилпенә. Кул-аяклар кылдый-пылдый селкенә.* Ш. Бабич.

МӘТӘЛДЕРҮ *ф.* Этеп, аяк чалып, төртеп егу. [*Сафура Илдуска:*] *Кагылмау түгел, мәтәлдереп кенә җибәрермен.* К. Нәҗми. || Нәрсәне дә булса аудару.

МӘТӘЛЧЕК *и.* Аяклар югары хәлдә, кулларга басып баш аркылы икенче якка әйләнеп төшү турында. *Ул хәзергә мәтәлчекне генә булдыра алмады, башын җиргә кадап, аякларын күтәрә башлауга яны белән лап итеп авып төште.* Г. Гобәй.

◇ **Мәтәлчек ату** — баш аркылы икенче якка әйләнеп төшү, мәтәлчек ясап тәгәрәү. *Кызый тау итәгендә --- кисеп аударган агач кебек авып киттe дә мәтәлчекләр ата-ата тәгәрәп барды.* Г. Ахунов.

МӘТӘЛЧЕКЛӘП *рәв.* Мәтәлчек атып. *Хәйдәр аның мәтәлчекләп әйләнгәнен күреп калды.* Ш. Усманов.

МӘТӘЛҮ *ф.* Сөртенеп егылып китү. *Аңа бөтен дөньяның асты өскә килгән, авыл да, нигезеннән кузгалып, түбәнгә мәтәлгән кебек булды.* А. Шамов. *Малай канау эченә мәтәлеп төште.* Г. Гобәй.

МӘХБҮС *и. иск. кит. шигъ.* Тоткын. *Мин дә киттем, күз нурына тартылып, мәрхүш булып, Шул сихерле дүнгәләктә коршалып, мәхбүс булып!* Ш. Бабич.

МӘХДҮМ *и. иск. кит.* 1. Хөрмәткә лаек ир кеше, хөрмәтле кеше.

2. Мулла улы.— *Чакырмыйча ярамый, берсе мәхдүм, икенчесе старшина малае.* Т. Гыйззәт.

МӘХДҮМӘ *и. иск. кит.* 1. Хөрмәткә лаек ханым-кыз.

2. Мулла кызы.— *Кечкенә мәхдүмәне гимназиягә биргәнсездер бит?* Ф. Әмирхан.

МӘХКӘМӘ *и. кит.* Хөкем итә торган идарә; суд, хөкем йорты. || Суд, хөкем. *Ул эшен тизлек белән югары мәхкәмәгә күчерү турында чаралар эзләргә тотынды.* Г. Ибраһимов.

МӘХЛУК *и.* Җан иясе. *Бөтен мәхлук белә яз җиткәнен: шатланалар чынлап.* М. Гафури. || Кешегә яки хайванга карата кызганып яки кимсетеп әйтелә. *Ул, бу мәхлуклар куркалар ахрысы дип уйлап, үзенчә мөмкин кадәр йомшаграк булырга тырышты.* Ә. Еники. *Ул сыер дигән мәхлук дуласа, аттан да узып китә икән.* Ә. Айдар.

МӘХРҮМ *с.* Берәр нәрсәсе булмаган, өлешсез, буш калган. *Болар инде бөтен фазыйләлләттән (яхшылыктан) мәхрүм кешеләр.* М. Гафури. | *рәв. мәгъ. Ул караңгы өйнең караңгы почмагында кояш нурларыннан мәхрүм үскән гөлчәчәк төсле боек булып үсәчәк.* Г. Гобәй. | *хәб. функ. Ул укый белә --- ләкин язудан бөтенләй мәхрүм икән.* Г. Ибраһимов.

◇ **Мәхрүм булу** — кемне яки нәрсәне дә булса югалту. *Михаил, бер күзеннән мәхрүм булу һәм туберкулезы көчәя баруга карамастан, һаман бирешергә теләмәде.* Ш. Камал. **Мәхрүм итү** — кемнең

дә булса берәр нәрсәсен алу, кемне дә булса берәр нәрсәсез, өлешсез калдыру. [*Илдар:*] *Күрә алмыйм мин бу Арсланны, йөрәктә тик ачу, кимсенү!.. Сөйгәнемнән мине мәхрүм иттең...* М. Җәлил. **Мәхрүм калу** — 1) нәрсәне дә булса ала алмый калу, үзенеке итә алмый калу. [*Зәмзәмбану:*] *Тор, күрше, тор, [өлешеңнән] мәхрүм каласың!* Т. Гыйззәт; 2) югалту, берәр нәрсәдән колак кагу. *Ул герман сугышында өч тапкыр яраланган, ике алгы тешеннән мәхрүм калган.* Сов. әд.

МӘХРҮМЛЕК *и.* Мәхрүм булу; мохтаҗлык. *Авыр бушлык, авыр тойгы, авыр мәхрүмлек тойгысы тагы йөзен күрсәтте.* Ф. Әмирхан.

МӘХШӘР *и.* **1.** *к.* мәхшәр көне. *Хаклык белән мәхшәргәчә бергә булыр өчен, син дә тиз бул, җиргә күмел.* Г. Тукай. *Яшьләр мунчаларда дәрес ала, Мәхшәр көтеп тора картлары.* М. Гафури.

2. *күч.* Ыгы-зыгы, мәш килү; шау-шу, тынычсызлык, буталыш. *Бер сәгатькә сузылды бу мәхшәр.* Ә. Айдар. *Гәрәй дә бик кызыксынып якынрак тартылды, тик мәхшәр арасында һичнәрсә аңларлык түгел иде.* А. Гыйләҗев.

Мәхшәр көне — ислам диненчә, яңадан терелгән кешеләрнең теге дөньяда җыелу көне.— *Аллаһе тәбарәкә вә тәгалә хәзрәтләре мәхшәр көнендә зур дәрәҗәләр бирер.* Ш. Камал.

МӘХӘББӘТ *и.* **1.** Кемне яки нәрсәне дә булса бик нык якын күрү, кемгә яки нәрсәгә дә булса чын күңелдән бирелгәнлек хисе. *Ана мәхәббәте. Туган илгә мәхәббәт.* □ [*Зариф та*] *бу балага биргән мәхәббәтен һәм назын үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр.* Ә. Еники. *Аның күңелендә гомер буе кулы эштән бушамаган, ару-талуны белмәгән кадерле карт әтисенә карата чиксез зур изге мәхәббәт, уллык мәхәббәте ташый иде.* Г. Әпсәләмов. [*Г. Камалның*] *ул елларда язган шигырьләре яшь совет иленә мәхәббәт, аның эчке һәм тышкы дошманнарына каршы рәхимсез көрәш уты белән сугарылганнар.* М. Гали. || Кемгә дә булса хөрмәт, симпатия кебек үз итү, якын итү хисе.— *Шул --- халыкта мөселманнарга карата нәндидер мәхәббәт бар, күрәсең.* Ә. Фәйзи.

2. Башка җенестән булган бер кешегә карата кайнар йөрәк хисе, ярату хисе; гыйшык. [*Нәфисә*] *рәсемне ертып учакка атты, әмма яшьтән сөйгән егетен, беркатлы саф мәхәббәтен алай тиз генә йөрәгеннән чыгарып ата алмады.* Г. Бәширов. || Шундый хис, гыйшык төшкән объект турында. *Димдә минем яшьлек мәхәббәтем, Димдә минем яшьлек сагышым.* М. Җәлил. || Гыйшык мөнәсәбәтләре. [*Кондратьев:*] *Алар арасындагы мөнәсәбәт нинди булгандыр, аны сын белмим. Һәрхәлдә мәхәббәт түгел, шулай ук ирле-хатынлы булу да түгел иде.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Мәхәббәткә (2 мәгъ.) бәйләнешле; мәхәббәт турындагы. *Мәхәббәт романнары.*

3. Нәрсә белән дә булса кызыксыну, нәрсәгә дә булса омтылыш, теләк, һәвәслек. *Романда Зыя ике нәрсәгә бирелгән хәлендә күрсәтелә. Берсе — Мәрьямгә, икенчесе—сәнгать-музыкага мәхәббәт.* Г. Нигъмәти.

МӘХӘББӘТЛЕ *с.* Сөйкемле, үзенә тарта, җәлеп итә торган. [*Рәшат:*] *Сез бер дә үзгәрмәгәнсез, һаман әүвәлге шикелле яшь, мәхәббәтле, матур.* Ф. Әмирхан.— *Син нинди мәхәббәтле!* М. Фәйзи.

МӘХӘББӘТЛЕЛЕК *и.* Мәхәббәтле булу (сыйфаты), сөйкемлелек.

МӘХӘББӘТСЕЗ *с.* Ямьсез, шыксыз, сөйкемсез. || Шаярып я ачуланып, яки үпкәләгән сыман итеп әйтелә.— *Мәхәббәтсез, тәмам саруымны кайнатып бетерде инде.* Г. Камал.—*Әбәү, мәхәббәтсез, нинди турсаеп утырган.* К. Тинчурин.

МӘХӘЛЛӘ *и. иск.* **1.** Шәһәр һәм авылның бер мәчеткә караган өлеше.— *Мөселманнар съездына безнең мәхәлләдән дүртәү.* К. Нәҗми. *Бөтен мәхәлләхалкы — ире, хатыны — муллага хөрмәт күрсәтәләр.* Ш. Камал.

2. Квартал.— *Базар мәхәлләсенә, байлар урамына якынаеп барам.* Г. Ибраһимов.

МӘХҮ: мәхү булу *иск.* — югалу, юкка чыгу, бетү. *Бетте, мәхү улды зәмин, һәм дә замана калмады.* Г. Тукай. **Мәхү итү** *иск.*— югалту, юкка чыгару, бетерү.

МӘЧЕ *и.* Күсе һәм тычканнар тота торган йорт хайваны (арслан, юлбарыс, каплан кебек хайваннар белән бер семьялыкка керә). *Аяк астында, Зиннәткә сыенып китә-китә, мәче мыраулап йөри.* А. Шамов. *Мәче як-ягына каранды, муенын сузып һаваны иснәде, аннары килгән юлы белән ялкау гына кайтып китте.* И. Гази.

Мәче башлы ябалак *зоол.* — караңгыда гына күрә алу сәбәпле, ауга төнлә чыга торган зур күзле, ыргак сыман томшыклы, йомры башлы ерткыч кош. *Карт агачларның черек куышларында утырган мәче башлы ябалаклар, тум-тугәрәк күзләрен фонарь төсле яктыртып, юл күрсәтәләр.* К. Нәҗми. **Мәче борчагы** *бот.* — мальва семьялыгыннан ал яки кызгылт чәчәкле берничә төр үлән үсемлекләрнең атамасы; *русчасы:* просвирняк, алтей. **Мәче бөтнеге** — озынча зонт сыман сары чәчәкле, озынчарак яфраклы, агулы сөтчел сыеклык чыгара торган чүп үләне, сөтлегән; *русчасы:* молочай. *Язын иң беренче күренә торган бу үсемлекне мәче бөтнеге дип тә йөртәләр.* Робинзон әзл. **Мәче койрыгы** — берьеллык чүп үләне; *русчасы:* подсвекольник. *Кәрешкә, мәтрүшкә, кәккүк чәчәкләре, мәче койрыгы, әремчек үләннәре --- белән чуарланган болынның хуш исле җиләс һавасына туйганчы иркәләндек.* М. Әмир. **Мәче үләне** — тамыры медицинада файдаланыла торган үлән үсемлек; *русчасы:* валерьяна.

◇ **Мәче ашаган** — әзсез югалган.

МӘЧЕТ *и.* Мөселманнарда: намаз укый, гыйбадәт кыла торган йорт. *Безнең йорт түбән оч мәчеттән үткәч тә уң кулда.* Ф. Әмирхан. *Мәчет янындагы каеннар зур булып үскәннәр.* И. Гази. || *с. мәгъ. Мәчеткә бәйләнешле. Мәчет капкасы.*

Мәчет карты — дин тота торган, мәчеткә йөри торган карт.

МӘЧЕТЛЕ *с.* Мәчете булган. *Мәчетле авыл.*

МӘЧКӘЙ *и. миф.* Убырлы карчык.— *Күрдегезме нинди [кыргый]? Мәчкәй шикелле ташланырга тора.* Ш. Маннур.

МӘШ: мәш килү — ыгы-зыгы килү, нәрсә белән дә булса бик мәшгуль булу. *Зиннәт мәш килеп эшләп йөргән шушы чуар халык арасыннан күзләре белән эзләнә башлады.* Г. Бәширов.

МӘШГУЛЬ *хәб. сүз. кит.* Нинди дә булса эш белән шөгыльләнү. *Һәрбере бер эш илә мәшгуль иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Эш белән бик мәшгуль булганлыктан, аның белән күрешеп сөйләшә алмадык.* М. Гали.

МӘШГУЛЬЛЕК *и.* Мәшгуль булу.

МӘШРИКЪ *и. кит.* Көнчыгыш. *Шәп атылгандай циркларда таган, Атыла [ул] мәшрикъ һәм дә мәгърипкә табан!* Ш. Бабич.

МӘШӘКАТЬ *и.* **1.** Борчу, борчулы эш, тынычлыкны бетерә, бөтен игътибарны таләп итә торган эш. *Бәләкәй мәшәкатьтән качкан — зурысына капкан.* Мәкаль. *Һәрхәлдә, йортка бәйләнсә, аның эше дә, мәшәкате дә бермә-бер артыр иде.* Ә. Еники.

|| Ыгы-зыгы. *Һәр җирдә тынычлык хөкем сөрә башлап, рәхәт җиләслек була, вә һәркем көндезге мәшәкать вә хезмәтләрдән ял итәргә ашыга.* Ф. Әмирхан.

2. Азап, авырлык. *Кайчандыр кышның караңгы кичендә сукыр лампа яктысында зур мәшәкать белән Габдулланың бабасына язылган хат исләреннән үк чыккан.* Ә. Фәйзи.

◇ **Мәшәкать чигү** — интегү, азаплану, авырлыклар күрү. **Мәшәкатькә салу** — борчу, мәшәкатьләү. **Мәшәкатькә юлыгу (грифтар булу)** — к. мәшәкать чигү.

МӘШӘКАТЬЛЕ *с.* **1.** Борчулы; ыгы-зыгылы.— *Тыныч яшәгән гомерне давыллы, мәшәкатьле тормышка алыштыра, ха-ха-ха!* Г. Кутуй. || Зур эш белән мәшгуль булган.—*Бик мәшәкатьле чагым иде, менә хәзер өй кузгатырга торам.* Г. Ибраһимов.

2. Авыр; катлаулы, кыен. *Ул сүзен әйтеп бетермәде, гүя артык сүз әйтү аның өчен үтә мәшәкатьле бер эш иде.* Г. Әпсәләмов.

3. Газаплы. *Мәшәкатьле һәм авыр походка чыгып киттек.* М. Җәлил.

МӘШӘКАТЬЛЕЛЕК *м.* Мәшәкатьле булу.

МӘШӘКАТЬЛӘНҮ *ф.* Борчылу, тынычсызлану. *Сез, иптәш, мәшәкатьләнмәгез, без үзебез дә башкарырбыз, иртәгә шушы вакытларда монда килеп чыгыгыз.* К. Тинчурин.— *Син, Шакир, бер дә борчылма, без барында сиңа әллә ни мәшәкатьләнергә туры килмәс.* Ә. Еники.

2. *ярд. ф. функ.* Маташу, азаплану, көчне һәм вакытны сарыф итү.— *Дәти, бара алмыймын, көчләп тә мәшәкатьләнмәгез.* М. Гафури. *Көтеп тә мәшәкатьләнмәгез, ул бикләнеп үк йокларга яткан.* Ш. Камал.

МӘШӘКАТЬЛӘҮ *ф.* Борчу, тынычсызлау. [*Малайны*] --- *мәшәкатьләмәсләр дигәндә, тагын кемдер ашыгыч, каты басып килде.* Г. Ибраһимов.

МӘШӘЛӘНҮ *ф. диал.* Көч куеп, куелган максатка, берәр нәрсәгә ирешергә тырышу; маташу. *Мәшәләнә торгач, әйләнеп менеп утырды.* Ф. Кәрим.

МӘШһҮР *с.* Танылган, атаклы, атказанган, шөһрәт казанган. *Әфәнделәр, программада мәшһүр җырчы Адамантов җырлаячак дип язылган.* Г. Камал. *Ичмаса, тәрҗемә аша булса да, мәшһүр рус шагыйрьләренең әсәрләре белән танышырга кирәк.* М. Гали. | *хәб. функ. Ул хәзергә кадәр дөньяда сирәк табылган әсәрләрне үзенә җыю белән мәшһүр.* Г. Гобәй.

МӘШһҮРЛЕК *и.* Мәшһүр булу.

МӘӘЛДӘҮ *ф.* Кәжә, сарык кычкыруын белдерә. *Сарыклар мәәлдәве.* ☐ [*Хәлим*] *кәҗә кебек мәәлди.* Каз. утл.

МӘӘМӘ: мәәмә итү — балалар телендә: „кыйнау, сугу“ мәгънәсендә. [*Рәхим*] *Аталарыгыз килеп, мәәмә итеп алып китмәсеннәр тагы үзегезне.* Ф. Әмирхан.

МӘӘЮС *с. иск. кит.* Өметсез, өмет өзгән. *„Бетәрмен“, димә, әй, дус, булма мәәюс.* М. Гафури. | *рәв. мәгъ. Мәәюс карый, аның күзләрендә Туйганлык бар залим дөньядан.* М. Укмасый.

МӘӘЮСЛЕК *и. иск. кит.* Өметсезлек. *Мәәюслеккә төшү.*

МӘӘЮСЛӘНҮ *ф. иск. кит.* Өметсезләнү, өметсезлеккә бирелү, өметсезлеккә төшү.

МӘҮЛА *и. иск. дини.* **1.** Ия, хуҗа.

2. Алла. *Берәүгә кыйлам, дисә ихсан мәүла, Бәхет яры дошманнан кыйлыр шөйлә.* М. Гафури. — *Нинди газаплар бу, я мәүла.* Ф. Бурнаш.

МӘҮЛИД *и. кит. дини.* Пәйгамбәрнең туган көне һәм шул көн үткәрелә торган бәйрәм.— *Атна кич килдеме, кадер, мәүлид бәйрәме булдымы, аңа көйләргә булсын, ул җырларга ярата.* Г. Ибраһимов.

МӘҖБҮР *с.* **1.** Ирексезләнгән, җәберләнгән. *Нигә соң син мескен, мәҗбүр мужикларны Талавыңда белә алмыйсың хәт-чикләрне.* Г. Тукай.

2. *хәб. сүз.* Нинди дә булса сәбәп белән яки ирексездән берәр эш эшләргә, башкарырга тиешлек турында.— *Ул мәсьәләне мин яңадан куярга мәҗбүрмен.* Ш. Камал.

Мәҗбүр булу — ихтыярсызлану, ирексездән нәрсәне дә булса эшләргә тиеш булу. *Шушындый вакытта кроватьта тик ятарга мәҗбүр булуы өчен Якуб бик газаплана.* И. Гази. *Шакир солдат катгый моментта авылдан китәргә мәҗбүр булган.* Г. Нигъмәти. **Мәҗбүр итү** — ирексезләп эшләтү, башкарту. *Тирәдәге хәлләр безне шулай саклыкка мәҗбүр итте.* М. Фәйзи.

МӘҖБҮРИ *с.* **1.** Берсүзсез, каршылыксыз, һичшиксез үтәлергә тиешле. *Мәҗбүри карар.* || Закон белән таләп ителә торган. *Мәҗбүри түләүләрне бетерү. Мәҗбүри уку.* | *хәб. сүз.* — *Хәзерге вакытта Советлар иленда унъеллык белем алу һәр кешегә мәҗбүри.* М. Гали.

2. Зарури рәвештә, үзеннән-үзе туган; булмыйча кала алмый торган.— *Бу Баязитлар, бу Азевлар бер үк тамырның мәҗбүри җимешләреме?* Г. Ибраһимов. || Булырга тиешле, зарури. *Монизм — тезмә һәм ярты тезмә азакларында мәҗбүри басымнар кулү.* Г. Нигъмәти.

3. Үз ихтыярыңнан, теләгеңнән башка, ирексездән, үз иркеңнән башка (эшләргә) тиеш булган. *Гәүдәләр тоткыннан котылып иркенәйгән кебек, күңелләр дә, әллә нинди бертөрле мәҗбүри авырлыктан ычкынып, киләчәкне уйларга керештеләр.* М. Гафури. || *рәв. мәгъ.* Ирексез рәвештә, теләмичә.

Мәҗбүри эш (хезмәт) — суд тарафыннан җәза буларак билгеле бер срокка билгеләнә торган хезмәт.

◇ **Мәҗбүри рәвештә** — үз теләгеннән башка; ихтыярсыз, теләмичә. *Бу мәҗбүри рәвештә өйдә утыру бер көн белән генә бетмәде.* Ә. Фәйзи.

МӘҖБҮРИЛЕК *и.* Ирексезлек, чарасызлык.

◇ **Мәҗбүрилек белән** — мәҗбүри рәвештә. [*Алиш белән Фоат*] *мәҗбүрилек белән эшкә керештеләр.* Ш. Маннур.

МӘҖБҮРИЯТ *и. иск. кит. к.* мәҗбүрилек. *Мостафинның атнага бер килгән буш киче --- шул мәҗбүриятне үтәүгә китә торган булды.* Ә. Еники. [*„Айгөл иле“ драмасы*] *бәхет турында, кешелек бурычы һәм мәҗбүрият турында, кешенең намусы һ. б. һ. б. турында уйландыра торган әсәр.* Г. Кашшаф.

МӘҖБҮРИЯТЛЕК *и. иск. кит. к.* мәҗбүрилек. *Кем белә? Бәлки ул аракычы ире кулында мәҗбүриятлектән генә яши торгандыр.* А. Шамов.

МӘҖЛЕС *и.* **1.** Җыелыш, утырыш. *Киңәш мәҗлесе.* ☐ *Саттар әфәнде Гатин мәҗлесне ябык дип игълан кылды.* К. Нәҗми.—*Сәгать сигездә дип чакырган мәҗлескә унда килгәч, эш ничек барсын?* Г. Камал.

2. Кунакка, ашка җыю яки җыелу. *Мәҗлес буласы көн Нәгыймә карчык иртәдән үк, бик зур эш алдында торган төсле, тынычсызлана башлады.* Ш. Камал.— *Шулай да мәҗлесне тузгыту өчен ярап куйды бу таш.* Ф. Хөсни.

3. *иск.* Пьесада: пәрдә яки күренеш. *Дүртенче мәҗлес. Унынчы мәҗлес.*

МӘҖЛЕСТӘШ *и.* Кем белән дә булса бер мәҗлестә утыручы. *Кояш нуры төшкән буш графин, рюм-*

калар, тәмәке төпчекләре мәҗлестәшләренә карата аңарда тирән нәфрәт тойгылары тудырдылар. К. Тинчурин.

МӘҖМУГА *и. иск. кит.* Җыентык, сайланма әсәрләр.— *Шәриф әфәнденең шигырьләр мәҗмугасы чыккан, укыдыңмы?* Ф. Әмирхан. *Кечерәк бер мәҗмуга аңа кызык тоела иде.* Г. Ибраһимов.

МӘҖНҮН *и.* Тиле, дивана, юләр, акылдан язган кеше, җенле кеше. *Шул рәвеш беткән иде җыр һәм нотык, чыкты да мәйданга бер мәҗнүн — өтек!* Ш. Бабич. *Яңгура --- төн уртасында [шул шигырьне] мәҗнүн кебек кабатлап йөри.* Г. Әпсәләмов. || Мәхәббәт, гыйшык утында газаплана торган кеше. *Ул көн буе үзалдына сөйләнеп, мәхәббәт җырлары җырлап, мәҗнүн кебек тилереп йөри.* И. Гази.

◇ **Мәҗнүн итү** — тилертү, акылдан яздыру.

МӘҖРУХ *с. иск. кит.* Яралы, җәрәхәтле. *Мәҗрух малайларның агалары тагын да ызгыш чыгардылар.* М. Гафури.

◇ **Мәҗрух булу** — яралану, җәрәхәтләнү.— *Унлап авыр, иллеләп җиңел мәҗрух булды.* Ш. Усманов.

МӘҖҮСИ *с.* Мәҗүсилеккә бәйләнешле. *Ул мәҗүси вакытыннан калган йола буенча, шыпырт кына яңгыр боткасы пешерә, очраган бер кешегә су сибеп йөри иде.* Г. Бәширов. || *и. мәгъ.* Потка табынучы кеше. *Әзе дә калмаган диннең, басып киткән мәҗүсиләр.* Г. Тукай.

МӘҖҮСИЛЕК *и.* Айга, кояшка, утка, потка һ. б. табынучылык. *Казан татарлары ислам дине кушкан гореф-гадәтләр һәм догалардан башка, мәҗүсилектән калган ырым һәм им-томнарны да [белә-ләр].* К. Насыйри.

МӘҖҮСИЯТ *и. иск. кит.* Мәҗүсилек. *Алар шул халыкның җыр вә әкиятләреннән рус халкының борынгы мәҗүсият заманындагы хәлләренә гаит хатирәләр табарга тырышалар.* Г. Ибраһимов.

МӘ'ҢГЕ *рәв.* **1.** Күп гасырлар буена, һаман, берөзлексез. *Менә урман, чиксез кара урман. Мәңге шомлы, мәңге караңгы.* Һ. Такташ. || Һәрвакыт. *Төннәребез хәзер көләч, айлы, Көндезебез мәңге кояшлы!* М. Җәлил.

2. Һич тә, һичкайчан. *Мәңге сүнмәс безнең мондый дуслык, Мәңге бетмәс бөек туганлык.* Ә. Исхак. [*Галиябану:*] *Мин мәңге аңа булачак түгел.* М. Фәйзи. *Ә сез гөлләр — гашыйкларның яры, Миңа иң саф чәчәк бирегез, Мәңге сүнмәс шатлык сибегез.* Ш. Маннур.

3. Бик күптән, күптәннән, озак вакыт. *Күпме вакыт яткандыр, Мисбах белә алмый иде, аңа ул менә шушы куаклар арасында мәңге ята кебек тоелды.* Г. Әпсәләмов.

4. Гомергә, гомер буена, бөтенләйгә.— *Авыл кызыгы белән генә рухланып, анда мәңге торып кала да алмыйм.* М. Фәйзи. *Илдар, серне мәңге саклау турында әйтеп, дәфтәр битенә ант язды һәм кул куйды.* Г. Гобәй.

МӘ'ҢГЕГӘ *рәв.* Гомергә, бөтенләйгә. *Мәңгегә аерылышу.* □ *Ул зимагорлык, бурлаклык тормышы белән мәңгегә бәхилләшергә уйлый.* М. Гали. *Дәй, мине баштан сөеп, бәгърем, дип алдаучы кыз! Мин китәм, ялгыз караңгы Сахраларга мәңгегә!* Һ. Такташ.

◇ **Мәңгегә (мәңгелеккә) күз йому** — үлү. [*Өч яшьлек кыз бала], кызамык белән авырып, --- мәңгелеккә күзләрен йома.* С. Рафиков.

МӘ'ҢГЕЛЕК **1.** *и.* Башы да, ахыры да булмаган вакыт агышы. || *с. мәгъ.* Беркайчан да бетми торган, гомерлек. *Кешеләргә мәңгелек бәхет, җиңелмәс көч бирә торган хикмәтле таш Бизмән тауда да бар икән.* А. Әхмәт. *Карарыбыз көрәш тарихында мәңгелек кара тап булып калачак.* Ш. Усманов. || Диниидеалистик философиядә: вакытка бәйле булмау, вакыттан тыш яши алу, вакытка бәйле рәвештә үзгәрмәүчәнлек хәле.

2. *с.* Күптәннән булган, яшәп килгән. *Дә ул --- ерып узгысыз калын томан астында, ул мәңгелек саз эчендә ниләр бар?* Г. Бәширов.

МӘ'ҢГЕЛЕККӘ *рәв. к.* мәңгегә.

МӘҢГЕЛӘШТЕРҮ *ф.* Гомергә онытылмаслык итү, киләчәк буыннар өчен истәлек итеп калдыру. *Геройның исемен мәңгеләштерү.* □ *Аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелүе турында язалар. Димәк, үлгәннән соң аның исеме мәңгеләштерелгән.* Т. Гыйзәт.

МӘҺАБӘТ *с.* **1.** Сокланырлык матур, сокланырлык күркәм. *Анда таза, көчле ергә хас әлекке мәһабәт сын, горур килбәт юк инде.* Ә. Еники. *Калын кара мыеклар аңа мәһабәт төс биреп торалар.* Р. Ишморат. || Тавыш турында: матур һәм көчле. *Мөхәммәтҗан бабай, көтүнең артыннан торып, бик мәһабәт тавыш белән каты итеп кычкыра.* М. Гали.

2. Зур, бөек, олуг. [*Миңа*] *шагыйранә мәһабәт Кавказ тауларының итәкләрендә үскән чәчәкләр [кирәк].* Ф. Әмирхан.

МӘҺАБӘТЛЕК *и.* Мәһабәт булу. *Тауларның мәһабәтлегенә, урманнарның тирән тынлыкта утыруларына карап исердем.* М. Гафури. *Монда куәт, монда искитәргеч Мәһабәтлек белән тантана.* Ш. Мөдәррис. *Мәһабәтлек һәм үзенә бертөрле олылык биреп торган мыегы да булмагач, ул бигрәк өтек булып күренә.* Г. Әпсәләмов.

МӘҺӘР *и. этн.* **1.** Кияү тарафыннан кәләшнең ата-аналарына бирелә торган акча. *Мәһәрнең билгеле хисабы юк, һәркемнең хәле кадәренчә, мәһәр салынадыр йөз тәңкә, икә йөз тәңкә, --- һәркемнең хәленә күрә.* К. Насыйри.— *Биш данә көмеш тәңкә чыгарып мәһәр бирдем.* К. Тинчурин.

2. *диал.* Кияү тарафыннан бирелә торган акча һәм мал. || *с. мәгъ.* Мәһәргә бирелгән. *Зәйтүнә --- әнисенең мәһәр калфагын чәченә әле тегеләй, әле болай кадап, купшыланып маташты.* Ф. Хөсни.

МӘҺӘРЛЕК *и.* Мәһәргә бирелә торган акча. *Кызга мәһәрлек — туена чәй-шикәрлек.* Мәкаль. || Мәһәргә җитәрлек.

МӨБАРӘК *с. иск. кит. дини.* Кадерле, хөрмәтле. *Мөбарәк урын.* □ *Мөбарәк рамазан ае якынлаша.* Ш. Камал. *Бөтен шәһәр халкы, музыка һәм курайлар илә җиде чакрым каршы барып, хәзрәтнең мөбарәк чабуларын үптеләр.* Ш. Мөхәммәдев. || Бәхетле, рәхәт.

◇ **Мөбарәк булсын** — котлы булсын.— *Мөбарәк булсын, Корбангали, улың бар!* Ш. Камал.

МӨГА'ЕН *кер. сүз.* Нәрсә турында булса чамалап, фараз итеп сөйләгәндә кулланыла: ахрысы, булса кирәк, шулай булырга тиеш.— *Бу чибәр егет, мөгаен, шул өч трактарның кырга чыгып китә алмыйча торуларын белеп килгәндер.* Ә. Еники. *Болар, мөгаен, бик усал ерткычлардыр, безнең өчен куркыныч-лардыр.* А. Алиш.

МӨГАЛЛИМ *и. иск.* Укытучы. *Якын танышларымнан бер мөгаллимнең Васильевода дачада торганлыгы хәтеремә төште.* К. Тинчурин. *Шул ук вакытта --- мөгаллимнәрнең һәммәсендә квартираларында озак тентүләр бара.* Г. Ибраһимов.

МӨГАЛЛИМЛЕК *и. иск.* Мөгаллим вазифасы, хезмәте.— *Димәк, сез мөгаллимлектән ваз кичмәкче буласыз?* Ә. Фәйзи.

МӨГАЛЛИМӘ *и. иск.* Укытучы хатын-кыз. *Шул көннән алып, авыл балалары аны „мөгаллимә апа" дип йөртә башладылар.* Г. Минский.

МӨГАЛЛИМӘЛЕК *и. иск.* Мөгаллимә вазифасы, хезмәте.

МӨГАМӘЛӘ *и.* Кемгә дә булса (карата) мөнәсәбәт; бер-беренә караш. *Дача халкы да бөтенләй бер гаилә шикелле булып беткәннәр, ияләшкәннәр, мөгамәләләре садәләшкән.* Ф. Әмирхан. *Кешеләргә тупас мөгамәлә күрсәтү кебек дорфа сыйфатларны бик каты тәнкыйтьләделәр.* Г. Әпсәләмов.

МӨГЕЗ *и.* **1.** Кайбер хайваннарның башындагы сөякчел каты үсенте. *Мөгезләр ерткычлардан сакланыу өчен хезмәт итәләр.* Зоология. *Хәлим, атасының нишләргә уйлавын аңламыйча, кәҗәнең мөгезеннән тарта башлады.* И. Гази. || *күч. сөйл.* Бәрелү, сугылудан маңгайга чыккан шеш.

2. Очы киңәеп бөрәк килгән кәкре торба формасындагы музыка коралы яки сигнал бирә торган җайланма; *русчасы:* рожок. *Көтүче мөгезе.*

3. Галантерея нәрсәләре ясау өчен кулланыла торган чимал. || Шуннан ясалган галантерея нәрсәләре. || *с. мәгъ.* Мөгездән эшләнгән. [*Исрафилов*] *кара мөгез тирәле күзлек кигән.* Ш. Маннур.

Мөгез катлау — кайбер җәнлекләрнең тиреләрендә барлыкка килә торган мөгез сыман каты катлау. *Кәлтәнең тиресе мөгез катлау белән капланган.* Зоология. **Мөгез сүрү** — күз алмасының алгы яктагы үтәли күренә торган өлеше.

◊ **Мөгез чыгару** — юк-бар нәрсәләр уйлап чыгару яки кирәкмәгән нәрсә эшләп ташлау. — *Җәй көне туй ясап, илдә булмаган мөгезне без генә чыгармыйк.* Г. Ибраһимов.— *Тотасың да үзеңчә бер мөгез чыгарырга тотынасың.* Ә. Фәйзи. **Мөгез чыгу** — 1) бәрелеп, сугылып, егылып яки башка сәбәптән маңгай шешеп чыгу; 2) зур дәрәҗәгә ирешү мәгънәсендә көлеп әйтелә. [*Әхмәт:*] *Җомга көн эшләү белән мөгез чыкса, Хәким белән Камалга чыгар иде.* М. Фәйзи. **Мөгезен сындыру** — кемне дә булса тынычландыру, ярсуын басу яки кимсетеп буйсындыру мәгънәсендә. [*Дурасов директор турында:*] *Мөгезен сындырып кайтармадылармы икән?* Ш. Камал.

МӨГЕЗБОРЫН *и. зоол.* **1.** Парсыз тояклылар семьялыгыннан танавы өстендә бер яки ике мөгезе булган коры җир хайваны (Африка һәм көньяк-көнчыгыш Азиядә яши); *русчасы:* носорог.

2. Башында мөгезе булган зур коңгыз.

МӨГЕЗЛЕ *с.* **1.** Мөгезе булган.

2. *күч.* Гадәти булмаган.— *Әллә машинада мөгезле кешеләр эшлиме? Бар да синең белән минем кебек.* Р. Төхфәтуллин.

◊ **Мөгезле түгел** — башкалар кебек үк, артык җире юк, башка кешеләргә охшаган, әллә кем түгел. — *Берегез дә мөгезле түгел әле!* Г. Бәширов.

МӨГЕЗЛӘНҮ *ф.* Мөгезгә әйләнү. || Мөгезгә охшап тору.

МӨГЕЗСЕЗ *с.* **1.** Мөгезе булмаган, мүкләк.— *Бар, әнә мөгезсез тана ашлык кырына кереп бара.* Һ. Такташ.

2. *күч.* Бернәрсәне дә абайламыйча йөрүче, тупас, тәртипсез хәрәкәтле, саксыз кыланучы, тыйнаксыз кешегә карата әйтелә. *Сукыр чебен кебек керәләр бит, мөгезсезләр, дип сөйләнә-сөйләнә Сөләйманов [дошманнарны] боз өстеннән берәм-берәм чүпли башлады.* И. Гази.

◊ **Мөгезсез сыер (тәкә) кебек** — 1) юлдагы кешеләрне, нәрсәләрне абайламыйча, игътибарга алмыйча, бәрелеп-сугылып баручы кешегә карата әйтелә; 2) гомумән тыйнаксыз, мәгънәсез, әдәпсез кешегә карата кимсетеп әйтелә.

МӨГЕЗЧЕЛ *рәв.* Мөгез сыман. *Тиредәге мөгезчел күзәнәкләр.*

МӨГРӘҮ *ф.* **1.** Сыер, үгез, буйвол кычкыруы турында. *Каядыр сыер мөгрәде, урам уртасында йоклап яткан казлар, уянып, үзара сөйләшеп алдылар.* М. Әмир.

2. *күч. кимс.* Сузып-сузып, аңлаешсыз авазлар чыгарып калын тавыш белән сөйләү. *Мулла үзенең мөгрәвен суза бирде.* Г. Ибраһимов. [*Картның*] *менә болай әч пошырып мөгрәве Сәфәргалинең ачуын кузгатты.* Ф. Хөсни.

МӨГӘРИЧ *и. сөйл.* Файдалы яки табышлы эштән соң, файда алган кеше тарафыннан оештырыла торган сый, сыйлау.— *Мөгәричне жәлләмәсәң, мин сиңа шул акчаңа аргамак алып бирәм.* М. Гали.

МӨГӘРИЧЛЕК *и. сөйл.* Мөгәрич алырлык, мөгәричкә җитәрлек.

МӨДАФӘГА: мөдафәга кылу *иск. кит.*— дошманнан саклану, үзен үзе саклау. *Бүре килә, Үгез кыйла мөдафәга, Бүрене сөзә һаман, читкә кага.* М. Гафури.

МӨДДӘТ *и. иск. кит.* Вакыт, срок, ара. *Ул алма мөддәте тулганда пешкән.* Г. Тукай.

МӨДИР *и.* Нинди дә булса оешма, учреждение, бүлек белән идарә итүче. *Кошчылык фермасына кергәч тә, уң якта ферма мөдире Сәлимәнең кечкенә генә бүлмәсе бар.* А. Әхмәт. *Губерна мәгариф бүлеге аны Кигәвенле авыл көтепханәсенә мөдир итеп җибәрде.* Ш. Камал.

МӨДИРЛЕК *и.* Мөдир булу, мөдир вазифасы. *Берничә еллар буена ул мөгаллимлекләр итте, мәдрәсә кисәкләрендә мөдирлек сыйфаты илә дә яшәде.* Г. Ибраһимов. *Заһид вакытлыча кафедрага мөдирлеккә билгеләнгәннән соң туган хәл, чыннан да, бик җитди иде.* А. Расих.

◊ **Мөдирлек итү** — мөдир булып эшләү, мөдир вазифасын үтәү. *Миңа хәтле пункт белән бер фельдшер мөдирлек иткән.* Г. Кутуй.

МӨДӘРРИС *и. иск.* Мәдрәсәдә өлкән укытучы. *Габдулланы терелтүгә Кәбир әфәндедән башка Гомәр хәлфә дә, хәтта мөдәррис үзе дә катнашты.* Ә. Фәйзи.— *Хәлфәләре генә түгел, бәлки мөдәррисенә кадәр карт аюдай тупас, песи башлы ябалактай томана.* Т. Гыйззәт.

МӨДӘРРИСЛЕК *и. иск.* Мөдәррис вазифасы, хезмәте.

МӨЕШ *и. диал.* **1.** Почмак.— *Нишләп шул чаклы сурәт асрыйлар? Җитмәсә кыйбла мөешенә куйганнар үзләрен.* К. Нәҗми.

2. Кечкенә куыш сыман урын.

МӨЗАКӘРӘ *и. иск. кит.* Фикер алышу, фикер алышып утыру. *„Сәмруг кош" системасында зур һава пароходлары йөртү турысында кызу-кызу мөзакәрәләр бара иде.* Ш. Камал. *Бу эшләрдә кылу кирәк мөзакәрә.* М. Гафури.

МӨКАДДИМӘ *и. иск. кит.* Сүз башы, кереш сүз. *Дсәргә язылган мөкаддимә.*□ *Әхмәт хәзрәткә мөкаддимәнең [кайбер] җирләрен укып күрсәтте.* Ф. Әмирхан.

МӨКАТДӘС *с. кит.* Изге, бөек, хөрмәтле. *Ай мөкатдәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз?* Г. Тукай.— *Минем өчен мөкатдәс булган барлык нәрсә белән ант итеп әйтәм, бу куркаклык түгел иде.* А. Шамов.

МӨКАТДӘСЛЕК *и. кит.* Изгелек, бөеклек. *Ул Маһруй битендә бер мөкатдәслек [күрә].* *Г. Газиз.*

МӨКИББӘН: мөкиббән булу (китү) — 1) йөзтүбән әйләнү; 2) берәр эшкә яки кешегә чиксез бирелү, шулар белән бик мавыгу.— *Кунак кызлары янында мөкиббән китеп утыра бит, әнекәем.* Г. Әпсәләмов. *Ибраһим ул кадәр үк мөкиббән китмәс иде.* Г. Камал.

МӨКӘММӘЛ *с. кит.* Камилләшкән, җитешкән. *Киләчәктә аның мөкәммәл бер театр булып нығыячагына ышаныч зур.* М. Җәлил. || *рәв. мәгъ.* Төгәл, камил. | *хәб. сүз. Бибиҗамал апаның күңеле хуш, кәефе мөкәммәл иде.* Ш. Хөсәенов.

МӨКӘММӘЛЛЕК *и. кит.* Мөкәммәл булу, камил булу, җитешкәнлек, өлгергәнлек.

МӨКӘММӘЛЛӘШТЕРҮ *ф. кит.* Камилләштерү.

МӨКӘММӘЛЛӘШҮ *ф. кит.* Камилләшү; тулылану. [*Татар совет әдәбияты*] *чыныгу, мөкәммәлләшә барды, күп милләтле совет әдәбиятының бер өлеше буларак --- җитди әдәбият булып җитеште.* Г. Бәширов.

МӨЛАЕМ *с.* Ягымлы, күркәм, сөйкемле. *Ишек ачылып, ишек арасында мөлаем бер кыз күренде.* Ш. Камал. *Бу вакытта ул урта яшьләрдәге мөлаем гына, ябык кына бер хатын иде.* Г. Әпсәләмов.

МӨЛАЕМЛАНУ *ф.* Ягымлылану, сөйкемләнү. [*Хәдичәнең*] *күзләре очкынланды, йөзе мөлаемланды.* М. Хәсәнов.

МӨЛАЕМЛЫК *и.* Мөлаем булу. *Аның тавышының мөлаемлыгы, йомшаклыгы күңелемне әллә нишләтә иде.* М. Әмир.

МӨЛДЕР-МӨЛДЕР *обр.ияр.* Тулып, мөлдерәп тору турында (күз яшьләренә карата). *Ул Миңлекәй турында сөйли башлый, сүзе белән бергә күзеннән мөлдер-мөлдер яшьләр тәгәри башлый.* Г. Ибраһимов.

МӨЛДЕРӘМӘ *с.* Бик нык тулган, ташып китәрлек булып тулган. *Малайның соңгы сүзе Гөлсем апага мөлдерәмә стаканны ташыткан тамчыдай тәэсир итте.* Г. Гобәй. [*Хәлимә*] *мәхәббәт белән, ялвару һәм ярдәм итәргә теләү белән мөлдерәмә күзләрен Сыртлановтан алмады.* Ш. Хөсәенов. || *рәв. мәгъ.* Бик нык, ташырлык булып. *Ул тавык шулпасы белән мөлдерәмә тулган тәлинкәне Малик кулыннан алды.* И. Гази.

◇ **Мөлдерәмә булу** — тулы булу. [*Хәбирнең*] *күңеле шатлык, наз һәм иркәлек белән мөлдерәмә булса да, теле дәшмәде.* Ш. Хөсәенов.

МӨЛДЕРӘТЕП *рәв.* Мөлдерәмә итеп, тутырып. *Күтәрик әле тостларны мөлдерәтеп, чыңлатып.* Ш. Маннур. || Күзне яшь каплау турында. *Китте бала күзен яшькә мөлдерәтеп.* Н. Исәнбәт.

◇ **Мөлдерәтеп карау** — 1) күзләрне төбәп, тутырып карау; 2) яшь аралаш яки күзләрне моңсуландырып карау. [*Алмачуар*] *бичаракаем, адәмнән болай акыллырак күзләре белән һәркемгә мөлдерәтеп карый.* Г. Ибраһимов.

МӨЛДЕРӘҮ *ф.* Тулып ташырга, түгелергә, чәчелергә тору. *Сөмбелләрнең кыягында таң чыклары мөлдери.* Ә. Ерикәй. *Шатлык яше мөлдерәде күзендә шул чагында.* З. Мансур. *Аналарның керфек очында Мөлдерләр өмет чыклары.* Г. Хуҗи.

◇ **Мөлдерәп карау** — *к.* мөлдерәтеп карау. *Сәфәргали сорау карашы белән әтисенә мөлдерәп бер карап алды.* Ф. Хөсни. **Мөлдерәп китү** — тулып, ташып, читкә агып китү. *Карт күңел түзмәде, күзләрдән берәр бөртек яшь чал сакал буенча мөлдерәп китте.* Г. Ибраһимов. **Мөлдерәп тору** — тулып, ташырга тору. *Светлананың күзләренә карады ул һәм бу күзләрдәге мөлдерәп торган сагыну моңын, әйтерсең лә, менә хәзер генә күреп алды.* Г. Минский. **Мөлдерәп тулу** — ташырдай, түгелердәй булып тулу. *Ике куллап алды ул мөлдерәп тулган тәлинкәне һәм әкрен генә үз алдына китереп куйды.* Г. Гобәй.

МӨЛКӘТ *и.* Милек, байлык. *Аңла, эшче, үзеңне, Ачып кара күзеңне. Бөтен дөнья мөлкәте Кем кулыннан төзелде?* Ш. Бабич. *Бер дә исең китмәсен, баланың әти-әнисеннән зур мөлкәт калгандыр әле.* Г. Гобәй.

МӨЛКӘТЛЕ *с.* Бай, байлыгы булган, мал-мөлкәте булган, хәлле.— *Мөлкәтле кешеләрнең барысы да диярлек аңа кул селтәделәр.* К. Нәҗми.

МӨЛКӘТЛЕЛЕК *и.* Мөлкәтле булу, хәлле, бай булу.

МӨМКИН *хәб. сүз.* **1.** „Нәрсәне дә булса эшләп, башкарып була, аның өчен шарт-җай бар" мәгънәсендә.— *Моңар бит бер кадак икмәк алып ашап, тамакны туйдырырга мөмкин.* Г. Камал. — *Теләсә нинди фонтанны борып куярга, туктатырга, хәтта язгы шарлавыкларны да тыярга мөмкин.* А. Шамов.

2. Нәрсәне дә булса эшләргә рөхсәт ителә, ярый. *Нәгыймә карчык аңа, --- Фазлуллин тора торган бүлмәгә урнашырга мөмкин --- икәнлекне сөйләде.* Ш. Камал. *Иптәш командир, ул шикле кеше кем булып чыкты, белергә мөмкинме?* А. Әхмәт.

3. Нинди дә булса эш-хәл турында: „булуы бар, булуы ихтимал" мәгънәсендә.— *Сугыш, ни әйтсәң дә, сугыш инде. Холык ягы начар сугышның, дәлә кайда ялкын уртасында өзелүе мөмкин сулышның.* Ә. Ерикәй.— *Арбаның ике үрчәсенә нык тотынып утырмасаң, арбадан төшеп калуың да бик мөмкин.* М. Гали.

Мөмкин кадәр (хәтле)— булдыра алганча, хәлдән килгәнчә. *Нәҗип кенә түгел, малайлар барысы да мөмкин кадәр гаскәриләргә охшарга тырышканнар.* Г. Гобәй.

МӨМКИНЛЕК *и.* **1.** Берәр эш-хәлнең булу-булмавын тәэмин итә торган хәл, шарт, җай. *Гомумән, көчләр яхшы һәм үсүгә бөтен мөмкинлекләр бар.* М. Җәлил.— *Медицина фәнендәге практиканың бөтен мөмкинлекләреннән файдаланып, авыруны коткарырга тырышабыз.* Ш. Камал.

2. Мөмкин булу, ихтималы булу, ихтималлык. *Эшнең чуалып китүе мөмкинлеген уйлап, Сарсымбай ялчы артыннан җылкычы атаны җибәрде.* Г. Ибраһимов.

МӨМТАЗ *с. иск. кит.* Кайсы ягы белән дә булса башкалардан аерылып торган, үзгә, югары, өстен. *Мәдрәсәдә бар иде бер таз малай, Бик шаян, шуклык белән мөмтаз малай.* Г. Тукай. | *рәв. мәгъ.* [*Җәләш*] *капканы тәмам шәһәр рәвешендә зур, чибәр, мөмтаз ясатып, башын төрле төскә буяп тимер белән яптырган.* Г. Нигъмәти.

МӨНБӘР *и. к.* менбәр.

МӨНДӘРИҖӘ *и. иск. кит.* Эчтәлек. *Һәр ике доклад буенча чыгарылган резолюциянең төп мөндәриҗәләре эшләрне көчәйтү кирәклеген алга сөрүдән гыйбарәт иде.* Ш. Камал. *Яңа форманы яңа мөндәриҗә, яңа идея белән генә тудырып була.* Һ. Такташ.

МӨНӘСӘБӘТ *и.* **1.** Нәрсәгә дә булса караш; кемгә яки нәрсәгә карата үзен тотышы. *Социалистик милеккә мөнәсәбәт.* □ *Аны гадилеге, ипташларча яхшы мөнәсәбәте һәм оста дәвалавы өчен яраталар иде.* А. Шамов.

2. Кешеләр арасында берәр сәбәп белән яки үзара аралашу нигезендә туа торган бәйләнеш. *Беркадәр корырак кеше булса да, айлар буена бергә ут астында йөрү аркасында, безнең арада шактый җылы*

бер мөнәсәбәт урнашкан иде. И. Гази. *Нәсел һәм кан ягыннан аларның Хәмзә байга һичбер мөнәсәбәтләре юк.* М. Гали. || Гыйшык, мәхәббәт бәйләнеше турында. *Хатынын икенче бер кеше белән мөнәсәбәттә гаепләп, ир аны халык каршында җәзалауга тапшыра.* Г. Нигъмәти.

3. Нәрсәгә дә булса бәйләнеш, катнашлык. *Никтер, бу эшләр белән Мәрьям туташ арасында бик аз гына да мөнәсәбәт юк төсле тоела.* Г. Ибраһимов. [*Гали*] *үткәндәге эшләр белән ике арада мөнәсәбәт тапмый иде.* М. Гафури.

4. Чынбарлыктагы предметлар, күренешләр арасында үзара бәйләнеш. *Аңның яшәешкә мөнәсәбәте.*

5. *сөйл. сир.* Сәбәп, йомыш. *Берәр мөнәсәбәт чыкса,* [*яшьләр белән*] *барып танышырга карар биргән идем.* Ф. Әмирхан.

Мөнәсәбәте белән — сәбәпле, уңай белән, нәрсәгә дә булса багышлап. *Бәйрәм мөнәсәбәте белән.*

МӨНӘСӘБӘТЛЕ *с.* Мөнәсәбәте булган. *Болар — Казан татарлары арасында мәгарифкә иң мөнәсәбәтле кешеләр.* Ф. Әмирхан.

Мөнәсәбәтле сүз *грам.*— Сөйләүченең үз фикерләрен чынбарлыкка мөнәсәбәттә бәяләп баруы өчен файдаланыла торган сүзләр төркеме. Мәсәлән: *„кем эшләми, шул ашамый“* җөмләсендә „кем, шул“ — мөнәсәбәтле сүзләр.

МӨНӘСӘБӘТЛЕК *и. лингв. к.* мөнәсәбәтле сүз.

МӨНӘҖӘТ *и. иск. дини.* **1.** Аллага ялвару, мактау сүзләре әйтү.

2. Дини тезмә әсәр.— *Берәр мөнәҗәтне укып җибәрер идең?* Ә. Фәйзи.

Мөнәҗәт әйтүче — мөнәҗәтне яттан сөйли белүче. *Ташаяк ярминкәсендә Хәйретдин бабайдан башка да мөнәҗәт әйтүче гарип татарлар күп була торган иде.* Г. Әпсәләмов.

МӨНӘҖӘТЧЕ *и.* Мөнәҗәт әйтүче, мөнәҗәт чыгаручы. *Бәхтияр — мөнәҗәтче, бәетче карт.* Т. Гыйззәт.

МӨРИТ *и. иск. дини.* Берәр мәшһүр башлыгы булган ишанга ант иткән турылыклы иярчен. *Ишан хәзрәтнең мөритләрен һәм башка байларны — барын хисапласаң, дүрт йөзләп кеше булгандыр.* Ш. Мөхәммәдев.

МӨРИТЛЕК *и.* Мөрит булу.

МӨРТӘТ *и.* **1.** *дини.* Үз диненә хыянәт иткән, башка дингә күчкән, үз диненнән ваз кичкән кеше. *Исеректә акыл булмас, мөртәттә иман булмас.* Мәкаль. [*Хәзрәт:*] *Бу сүзе белән ул кяфер булды, мөртәт булды.* Ф. Әмирхан.— *Бүген үк Миртимер мөртәтне мәдрәсәдән куыгыз.* Т. Гыйззәт.

2. *сөйл.* Хыянәтче, сатлык җан. [*Шаһиәхмәтов:*] *Кеше әйтеп кеше ышанмас, үз мөртәтләребез шулай эшләде бит.* Ф. Хөсни.

3. Сүгү, кимсетеп әйтү сүзе.— *Мөрит исемле мөртәтләр күп бит.* Г. Тукай.

Мөртәт китү — диннән ваз кичү.

МӨРТӘТЛЕК *и. иск.* Мөртәт булу. *Интеллигенция арасында өметсезлек, идеалдан ваз кичү, мөртәтлек кебек күренешләр килеп чыкты.* Х. Госман.

МӨРӘҖӘГАТЬ *и.* Кемгә дә булса юнәлдерелгән чакыру, үтенү сүзе; өндәмә. *Тынычлык яклаучыларның бөтендөнья конгрессы мөрәҗәгате.* □ *Бәлки, хәзер күрше районнарга мөрәҗәгать кабул итәрбез.* Ш. Мөдәррис.

◇ **Мөрәҗәгать итү** — 1) дәшү, эндәшү, сүз кушу. *Менә нәрсә,— диде ул, яңадан Шәмгун картка мөрәҗәгать итеп,— мин бүген Күккүздә булдым.* А. Шамов; 2) нәрсә белән дә булса эш итү, шөгыльләнү, тикшеренү. *Фольклорга мөрәҗәгать итү, аны өйрәнү һәм аннан файдалану --- Тукайга да уңышлы йогынты ясадылар.* Г. Ибраһимов.

МӨРӘҖӘГАТЬНАМӘ *и. иск.* Язма мөрәҗәгать; мөрәҗәгать язуы.

МӨСАФИР *и. кит.* Юлчы. *Безнең мөсафирларыбыз бу вакытта инде дачаның урманына килеп җиткәннәр иде.* Ф. Әмирхан. *Без мөсафир әфәнденең хатын кыскартып бастык.* Ш. Мөхәммәдев.

МӨСАФИРЛЫК *и. кит.* Мөсафир булу хәле.

МӨСАФИРХАНӘ *и. кит.* Юлчылар туктый торган номерлар. *Карьерасы баш эйләнгеч тизлектә күтәрелә баручы Гайфи Ижбулдин „Болгар“ мөсафирханәсенә күчте.* К. Нәҗми.— *Бу вакытта Тукай мин тора торган мөсафирханәдә тора иде.* Ф. Әмирхан.

МӨСЕЛМАН *и.* Ислам динендәге кеше, ислам динен тотучы. [*Сәйдәш бабай:*] *Дфәнделәр, мөселман кыяфәтен бозмагыз, митингларга кәләпүш илә килегез.* Ш. Мөхәммәдев. || *сөйл.* Татар, татар кешесе. — *Үз шәһәреңдә, үз мөселманыңның шундый бер газетасы булсын да, синең шуннан хәбәрең булмасын имеш!* Ш. Камал.

МӨСЕЛМАНЛЫК *и.* Мөселман булу. *И явызлар! --- Мөселманлыктан көлдегез. Галимнәрне танымадыгыз. Тугры сөйләгәннәрне кыстыгыз, издегез.* Г. Тукай.

МӨСЕЛМАНЧА *рәв.* **1.** Мөселманга хас булганча.

2. *сөйл.* Татарча.— *Урыс киеме булгач, барыбер лә инде ул, энем, пальто дибез без аңа, мөселманча исеме шулай аның.* Ш. Камал.— *Беләсең бит, бүген мөселманча театрның беренче башлана торган көне.* Г. Камал.

МӨСТӘКЫЙЛЬ *с.* **1.** Кемгә дә буйсынмаган, бәйсез, аерым. *Мөстәкыйль илләр.* || Башкалар рәтеннән, арасыннан аерылып чыккан, башкалардан аерым. *Фәннең мөстәкыйль бүлеге.* □ *Ошбу көчләр мөстәкыйль, һәрберсе бер юлдан бара.* М. Гафури.

2. Башкалар ярдәменнән, җитәкчелегеннән тыш эшләүгә, фикерләүгә сәләтле. *Мөстәкыйль мин дөньяда, Теләгән эшемне эшлимен.* М. Гафури. || Үзбашка, җитәкчелектән башка. *Мөстәкыйль эшләүгә күчү. Укучыларда мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру.*

3. Чит ярдәмнән, җитәкчелектән башка, үз инициативасы яки үз көче белән эшләнгән, үзенчәлекле. *Төрек әдәбияты тәхте тәэсирендә язылган шигырьләрендә дә Габдулла әфәнде мөстәкыйль вә гүзәл тасвирлар дәрәҗ итәдер.* Ф. Әмирхан. || Чит йогынтылардан башка; оригиналь.

МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК *и.* Мөстәкыйль булу. *Үзенең мөстәкыйльлеге белән ул минем дә мәхәббәтемне үзенә тарта.* Ә. Фәйзи. [*Картның*] *бөтен торышында беркадәр аптырашка калу, нәрсәдер көтү һәм шул ук вакытта үзенең мөстәкыйльлеген сакларга тырышу да бар иде.* А. Шамов. *Бу республикалар XX гасыр башына кадәр мөстәкыйльлекләрен саклап килделәр.* Яңа тарих.

МӨТӘВӘЛЛИ *и. иск.* **1.** Милек-мөлкәт эшләре белән шөгыльләнүче кеше.

2. Мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кеше.

МӨФТИ *и. дини.* Мөселман руханилары башлыгы. *—Кем дә кем төшендә мөселманнарга мөфти булып, елга өч мең жалованье алып, мөселманнар файдасына ике тиенлек эш кылмаса, хәвефледер.* Ш. Мөхәммәдев.

МӨХАЛЬ *с. иск. кит.* Мөмкин булмаган, тормышка ашардай булмаган. *Шуның өчен кавышу мөхаль булган Ярга язган хатлар шикелле.* М. Җәлил.

Дәлилне китерсәң, аллага һичбер мөхаль эш юк диде. М. Гафури.

МӨХБИР *и. иск. кит.* Хәбәрче, корреспондент. *Газетабызның мөхбире Мөбарәкша Хәлилов бу җыелышның әһәмиятен сөйләде.* К. Нәҗми.

МӨХБИРЛЕК *и. кит.* Мөхбир булу; мөхбир хезмәте һәм вазифасы. *Мөхбирлеккә тәкъдим итү.* □ *Шимбә көн „дәһислах" мөхбирлеге сыйфатым белән Казанда мәдрәсәләр берләштерү фикерләрен сорашып йөрдем.* Ф. Әмирхан.

МӨХТӘРӘМ *с. иск. кит.* Хөрмәтле, хөрмәт ителә торган. *Мөхтәрәм, зур шагыйрь, мәшһүр шагыйрь бар бездә дә,— дип шатланам.* Ш. Бабич.

МӨХӘРРИР *и.* Редактор. *Газета мөхәррире.* □ [*Суфый:*] *Мин мөгаллимәсенә дә, мөхәррирена дә, миллионерына да керә алам.* К. Тинчурин.

2. *иск.* Язучы, журналист. *Рус мөхәррирләреннән укыган нәрсәләремнең һәммәсен башымнан уздыра башладым.* Ф. Әмирхан.

МӨХӘРРИРЛЕК *и.* 1. Редакторлык, редактор эше һәм вазифасы.

2. Язучылык, журналистлык. *Үзе язган әйбернең басма китап рәвешендә чыгуы Габдуллада көтелмәгән шатлык белән бергә беренче мөхәррирлек горурлыгы тудырып өлгерде.* Ә. Фәйзи. *Мин үзем буржуй түгел, мин дә сезнең кебек үз кул көче белән яши торган, дәрестән, мөхәррирлектән килгән жалованье белән кичәнгән бер зыялы.* Г. Ибраһимов.

МӨХӘРРӘМ *и. кит.* Мөселманнарда — һиҗри елының беренче ае атамасы. *Беренче мөхәррәмдә мәдрәсәдә бик зур бәлеш мәҗлесе ясап, шәкертләрне таш санау фәненнән имтихан кылмак булалар.* Ш. Мөхәммәдев.

МӨШКЕЛ *с.* Авыр, кыен, читен; начар. *Мөшкел мәсьәлә.* | *хәб. функ.* [*Галимҗан:*] *Ул мәсьәлә берни түгел, хәлең мөшкел, кыз бала.* Т. Гыйззәт.

МӨШКЕЛЛЕК *и.* Авырлык, кыенлык, читенлек; авыр, кыен булу. [*Әбелхарис:*] *И падишаһым, бу мөшкеллекнең аслын бу кыздан сорамак мөмкиндер.* К. Насыйри. *Зәйнуллинга бу мөшкеллекне чишәргә юл табылды.* С. Җәләл.

МӨШКЕЛЛӘНҮ *ф.* Авырлану, авырлашу, кыенлашу, начарлану (эш-хәл турында). *Сферик шарлар һәм баллоннар янында ялкын кызуы арта, янгын сүндерүчеләрнең хәле мөшкелләнә бара иде.* Г. Ахунов.

МӨШКӘ *и.* 1. Тегермәндә: он төшә торган улак сыман җайланма. [*Тегермән ташлары*] *әйләнергә тотына, мөшкәдән кершәндәй ак он агуын өмет итеп килгән агайның капчыгына көрпә коела башлый.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Комбайнда: бункер.

◇ **Мөшкә башында булу (тору)** — нинди дә булса эшнең башында тору, хуҗа булу. [*Мортаза Мәдинәгә:*] *Белгәнеңчә, мөшкә башында без барабыз бит әле.* М. Хәсәнов.

МӨШКӘТ *и. иск. к.* мускат.

МӨШТЕК *и.* Тартканда папирос, сигарет кыстырыла торган җайланма.— *Тартырга бармы? Бар иде дә, мөштек кенә калды* [*тәмәкесе бетте*]. И. Туктар. — *Гафу итегез, иптәш кем, мөштегегезне әйтәм, бик матур икән, --- каян алдыгыз, диюем.* Соц. Тат.

МӨШТӘРИ *и. иск.* Газета-журналларга язылучы, газета-журналлар алдыручы. *Хөсәен яңа чыккан рисаләләрне укый һәм менә икенче ел „Тәрҗеман"ның да мәштәрие иде.* Ф. Әмирхан.

МӨЭМИН *с. дини.* Динле, дин тотучы, мөселман. *Ул юаш кына, инсафлы гына бер егет. Артык мөэмин, артык саф күңел.* Г. Ибраһимов.

МӨӘННӘС *и. иск. лингв.* Хатын-кыз җенесе.

МӨҢГЕРӘҮ *ф. диал. к.* мөгрәү. *Сөт аз бирә торган сыер күп мөңгери.* Мәкаль.

МӨҢРӘҮ *ф. диал. к.* мөгрәү. *Кызыл сыер, аларның туп-туры үзенә таба килүләрен күргәч, моңлы тавыш белән мөңрәп җибәрде.* М. Гафури.

МӨһЕЛДӘҮ *ф.* Әкрен генә кешнәү (ат турында). *Хөснулла, атның мөһелдәп торуына карамастан, тиз арада атны җикте дә чыгып китте.* Ш. Камал.

МӨһЕР *и. иск. к.* печать. [*Иблис:*] *Сизмисез сез әчтә ниләр янганын, Дошманы булдым гомерлек алланың ... Җиргә ник ташланганымны белмисез, Маңгаемда бу мөһерне күрмисез.* Ш. Бабич.— *Бу ике хәреф безнең мәхәббәтләребезне мәңгегә беркетүче мөһер булсын.* Ш. Хөсәенов.

◇ **Мөһер (сугу) басу** — 1) печатьләү. *Ике карт тамга салды, староста мөһер басты да кәгазьне әткәйгә бирде.* Г. Ибраһимов. 2) *күч.* атама, кушамат бирү.— [*Тормышындагы*] *хәлләр, ни өчендер,* [*Байгилдиевка*] *„социалистлык" мөһерен бастылар.* К. Тинчурин.

МӨһИМ *с.* 1. Әһәмиятле, җаваплы, җитди.— *Монда мин мөһим эш белән килдем.* Ф. Бурнаш.

2. Актуаль, бик кирәкле. *Дәрләрдә җанлы характерлар өстендә эшләү — хәзер яңа чорның мөһим бурычы.* М. Җәлил.

МӨһИМЛЕК *и.* Мөһим булу.

МҮК *и.* Куе булып җиргә ябышып үсә торган, тамырсыз һәм чәчәксез, споралы яшел үсемлек. *Су мүге. Торф мүге.* □ *Кошкай ояга мүк ташый.* Дәрдмәнд. *Әкрен генә җилгә лепердиләр сазда мүкләр.* Ә. Ерикәй.

Мүк җиләге — 1) мүкле, сазлыклы урыннарда үсә һәм җимеш бирә торган куак үсемлек; *русчасы:* клюква; 2) шул куакның әчкелтем кызыл җиләге. *Мүк җиләге ерактан кызыл чәчәкләргә, якыннан кан тамчыларына охшый.* И. Туктар.

МҮКЕЛДӘТҮ *ф. гади с.* Яратып, аппетит белән ашау турында. *Сафа абый, алдына гына карап утырган килеш, бик тырышып, коры ипи мүкелдәтә.* Г. Бәширов.

МҮКЛЕ *с.* Мүк үскән. *Мүкле урын. Мүкле таш.*

МҮКЛӘГЕЧ *и. махс.* Төзелештә: мүк кыстырганда файдаланыла торган махсус җайланма.

МҮКЛӘК с. 1. Мөгезсез. *Мүклək сыер.* □ [*Кияүгә*] *иртәсен-кичен җылы сөт эчерәсе булыр дип әйтеп, узган яз мүклək кенә булса да бер кәҗә дә алдылар.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Елгыр, тыкшынучан, шома (кеше турында).

3. *күч.* Йомшак характерлы, җебегән, булдыксыз, принципсыз. *Мүклək кеше.*

МҮКЛӘНҮ *ф.* 1. Мүк үсү, мүк белән каплану. *Мүкләнгән таш инде, Кайралмассың күсәк белән дә.* Ш. Маннур. *Юлның ике ягында җир өсте генә түгел, агачлары да мүкләнеп торган калын урман.* Каз. утл. *Яткан таш мүкләнер, йөргән таш шомарыр.* Мәкаль.

2. *Төш. юн. к.* мүкләү.

3. *күч.* Рухи яктан артта калу, үсмәү, белемеңне арттырмау.— *Шулай булгач, нишләп мин авылга китеп мүкләнергә тиеш?* Н. Фәттах. || Максатсыз, идеалсыз яшәү, бернәрсә белән дә кызыксынмау. [*Секретарь:*] *Әгәр синең күңелең тәмам мүкләнгән булса, синнән бернәрсә дә чыкмас.* Г. Әпсәләмов. *Менә шулай, укырга барырсың. Җитәрлек яттың мүкләнеп.* К. Басыйров.

МҮКЛӘҮ *ф.* Мүк кыстыру (бүрәнә, агач арасына, ярыкка). *Өй салуның нәрсәсе бар: мүклисе дә чут-*

лыйсы. Әйтем.— *Каенатай куа: браматтa йөрмә, үз өеңне үзең мүклә, ди.* Ф. Бурнаш.

МҮКЛӘҮЧЕ *и.* Мүкләү эшен башкаручы.

МҮКӘЙЛӘП *рәв. диал. к.* мүкәләп. *Йөри башлаганчы бала да мүкәйләп йөри.* Әйтем.

МҮКӘЛӘП *рәв.* Дүрт аяклап, тезләр һәм куллар ярдәмендә. *Һай, гомер дигәнең, җил шикелле исеп кенә тора, әле кайчан гына дүрт аяклап, мүкәләп йөргән бала иде, ә бүген 13 яшь тула үзенә.* А. Әхмәт. *Бибкәй ишектән мүкәләп барып чыгып китә.* М. Фәйзи.

Н

Н Татар алфавитында ундүртенче хәреф.

НА *ы.* Ат куганда, әйдәгәндә (күбесенчә сузып) әйтелә (на-а-а!). *„На, рәхмәт яугыры, урам уртасында нишләвең бу?“ — дип, Миңнулла үзенең биясен оялтып караса да, --- ат кыймылда[мады да].* И. Гази. *Җигеп, „нна... а!“ дияргә өлгерә алмадык, кара тимер --- арбаны җилтерәтеп алып менеп китте.* Г. Ибраһимов.

НАБАБ *и.* Һиндстанда әре мөселман аристократлары титулы һәм шул титулга ия булган кеше.

НАБАТ *и.* Берәр төрле һәлакәт, куркыныч булуны белдереп чаң кагу.

Набат сугу — *к.* набат. *Каланчада шул көн пожар чыккан, Ләкин беркем набат сукмаган.* М. Җәлил. *Набат сугып туктатмакчы була Дулкынланган эшче диңгезен.* М. Гафури.

НАБО'ЙКА *и. махс.* Аяк киеменең үкчәсенә сугыла торган күн яки резин кисәге. *Набойка сугу.*

НАБОР *и. махс.* Типографиядә ни дә булса басар өчен җыелган хәрефләр. [*Касыйм*] *калган ике полоса наборын соңгы тапкыр карап чыккан булып өстәл янына килде.* Г. Минский. *Кул көче белән йөртелгән агач стан --- берьюлы урта формат 8 полоса [бит] набор сыйдырган.* И. Рәмиев.

НАБО'РЩИК *и. махс.* Типографиядә хәреф җыючы эшче. *Әй, наборщик, үзеңә дә түгел зәвык, Яңлыш тезсең, җәзасы бар дөньяда ук!* Ш. Бабич.

НАБО'РЩИКЛЫК *и. махс.* Наборщик һөнәре, наборщик эше.

НАВА'ГА *и. зоол.* Тәрәч балыклары семьялыгыннан ашарга яраклы диңгез балыгы. *Ак диңгездә сельдь һәм навага балыклары тотыла.* СССР физ. геогр.

НАВИГА'ТОР *и. махс.* Навигация (3 мәгъ.) белгече.

НАВИГА'ЦИЯ *и. махс.* 1. Корабльләр, пароходлар йөртү фәне һәм сәнгате.

2. Урындагы климатик шартларга карап, елның корабльләр, пароходлар йөри ала торган вакыты, сезоны. *Октябрь аенда инде елга өсте кар белән капланса, навигация туктала.* Э. Маликов. *Академик Отто Бөек Төньяк диңгез юлын бер навигациядә үтеп булуын сөйли.* А. Алиш.

3. Пароходлар йөреше, корабльләр йөреше.

НАВО'ДКА *и. хәрби.* Билгеләнгән ноктага ату өчен тупны төзәү, көпшәне тиешле якка юнәлтү.

НАГА'ЙКА *и.* Каештан үрелгән кыска камчы. *Казаклар, жандармнар --- берничә эшчене тотып алганнар да --- нагайка белән башларына бәрәләр.* М. Гафури. *Полицейскийның нагайкасы [Садыйкның] сул як иңбашын утта көйдергәндәй ачыттырып үтте.* А. Расих.

НАГАН *и.* Әйләнмә барабанлы, махсус системадагы револьвер. *Гатаулла, кулына наган тоткан килеш, ике уртада бертуктаусыз йөреп тора.* К. Нәҗми. *Наганын каешына кыстырган яшь кызылармеец беренче булып килеп җитте.* Г. Гобәй.

НА'ГЕЛЬ *и. тех.* Зур агач яки металл кадак.

НАГРУ'ЗКА *и. махс.* Нинди дә булса урынга тәэсир итүче көчләр җыелмасы. *Көндезге сәгатьләрдә сынау нагрузкасы уңышлы алып барылды.* С. Рафиков.

НАДАН *с.* 1. Укый-яза белмәүче. [*Хөснулла:*] *Без бит авыл кешесе, надан халык, үзең беләсең, гимләзияләр күрмәдек.* Ш. Камал. || Аз белемле, сөйләшкәндә яки язганда хата җибәрүче.

2. Берәр өлкәдән тулы хәбәрдар булмаган, үз эшен, үз белгечлеген начар белүче. *Яңадан бераз уйлап торганнан соң, мин янымдагы теге гарәпчә белми торган надан студентны үземә ярдәмгә чакырмакчы булдым.* Ф. Әмирхан. | *и. мәгъ. Зарарлы эшне дә файдалы дип әйткән наданнар күп.* М. Гафури. *Солтан, Шмитның татар теленә язылган шигырьләрен кулына алгач, кинәт үзенең надан икәнлеген аңлады.* А. Расих.

НАДАНЛЫК *и.* Надан булу хәле, сыйфаты. *Наданлыкны бетерербез, белемнәрне арттырырбыз, яшьләрне яңа тормышка өндәрбез.* Ф. Бурнаш. || Билгеле бер өлкәне белмәү. *Үземдәге наданлыкны, тәҗрибәсезлекне, көчсезлекне сизү шундый авыр булды.* М. Әмир. *Авыр — авырлыктан түгел, ә укыган саен үзеңнең наданлыгыңны белә барганга авыр.* Һ. Такташ.

НАДЗИРА'ТЕЛЬ *и.* Революциягә кадәрге Россиядә тоткыннарны күзәтеп, карап, тикшереп торучы хезмәткәр. *Надзирательләр, минут саен диярлек тимер ишекнең кечкенә тимер күзен ачып, сагалап кына йөриләр.* Г. Ибраһимов. *Надзирательләр чыгып киткәч, [Илсөяр] уңга-сулга чайкалып торды да бусагага тезләнде, аннары, сызланып, идәнгә йөзтүбән авып төште.* Г. Гобәй.

НАДЗИРА'ТЕЛЬЛЕК *и.* Надзиратель вазифасы яки хезмәте.

НАДЗОР *и.* Саклау, контроль һ. б. максатлар белән кемне яки нәрсәне дә булса күзәтеп, тикшереп тору эше.

НАДИР *с. иск. кит.* Сирәк очрый торган, сирәк. *Безнең күңелләр үзең яраткан надир мәгъбүзләр — матур җаннар каршысында сәждә итәргә тели.* Г. Ибраһимов.

НАДСМО'ТРЩИК *и.* Күзәтеп торучы яки күзәтеп торып эшләтүче. *Эшчеләр надсмотрщиклар --- рөхсәтеннән башка --- китә алмаганнар.* СССР тарихы.

НАЕ'ЗДНИК *и. махс.* Ат өстендә төрле хәрәкәтләр ясаучы артист. *Цирк наезднигы.*

НАЁМЩИК *и. иск. сөйл.* Икенче берәү урынына ялланып солдатка киткән кеше.— *Безнең әхмәтҗанга падишаһ ризыгын ашарга язмагандыр инде, --- күрше авыл алпавытының Миндум атлы көтүчесе безгә наёмщик булырга риза булды.* Г. Газиз.

НАЖДАК *и.* Пыяла, металл, таш һ. б. ш. әйберләрне шомарта, ялтырата, металлдан ясалган төрле нәрсәләрне чистарта торган минераль порошок. *Алюминий окисе катлавын наждак порошогы ярдәмендә кырып алырга --- мөмкин.* Химия.

НАЖДАКЛЫ *с.* Наждактан эшләнгән, наждак ябыштырылган. *Наждаклы кәгазь.*

НАЗ *и.* 1. Иркәләү; йомшак мөнәсәбәт, иркәлек. *Зариф --- бу балага биргән мәхәббәтен һәм назын үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр.* Ә. Еники. *Менә Хәбир, наз тулы күзләрен Мәдинәгә текәгән килеш, сыңар кулы белән гамма уйнады.* Ш. Хөсәенов. *Әтисенең назы [Габдулланың] кайгысын сүндерми, дөрләтә генә.* Ә. Фәйзи.

2. Каприз, көйсезлек. *Бу — әсманың коры бер көкетлыгы, коры бер назыдыр.* Ф. Әмирхан. || *күч.* Мәшәкать, борчу. *Кызы барның назы бар.* Мәкаль. *Бал кортының балы бар, балга хәтле назы бар.* Мәкаль.

НАЗАР *и. иск. кит.* 1. Караш, игътибар, илтифат, күз салу. [*Җәмилә*] *мыскыл назары белән бага.* М. Гафури. *Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китим әле: халкыбыз хакыйкый ысулда язылган хикәя вә романнарга тиеш назар илә карый алмый.* Г. Ибраһимов.

2. Караш, уй. *Әй, Базаргөл, матурлыкта базарың бар, Минем сиңа ике төрле назарым бар.* Ш. Бабич.

Назар кылу — карау, игътибар итү, күз салу. *Тирә-ягыңа бер назар кыл: Хода биргән күзең бар.* Ш. Мөхәммәдев.

НАЗАРИ *с. иск. кит. к.* теоретик I. *Без бу соңгы сүзне мәсьәләнең тик назари ягын карап түгел, хыялның гамәлгә керә алу ягын игътибарга алып әйтәбез.* Г. Ибраһимов.

НАЗАРИЯ, НАЗАРИЯТ *и. иск. кит.* Теория, доктрина. [*Г. Нигъмәти*] *кыска, ләкин ачык җөмләләр белән безгә коммунизм нигезләрен, --- гыйльми коммунизм назариясенә нигез салучылар, бу назарияне практикада үткәручеләр турында --- бик тулы иттереп сөйләп бирә.* Каз. утл.

НАЗЛАНУ *ф.* 1. Иркәләнү. *Күңелем йомшара, вакытлыча миндә кечкенә баладай иркәләнү, назлану хисләре уяна.* Г. Минский. [*Жәүдәткә*] *семьясының җылы күңенында озак назланырга туры килмәде.* Г. Бәширов.

2. *сөйл.* Кылану, боргалану-сыргалану. [*Мортаза:*] *Исәнме, Миңсылу!* [*Миңсылу:*] *(бераз назланып). Хәзергә ярыйсы әле, рәхмәт.* Р. Ишморат. *Матур кызның гадәте шул: Сөймәсә дә үз итеп, Бер елмаеп, бер назланып, Тик йөри кызык итеп.* М. Җәлил.

3. Берәр нәрсәне эшләмичә ялындырып тору. *Шәкерт әлек бераз назланып торган булса да, соңыннан җиләннәрен, бүрекләрен салып, мәйданга чыкты.* М. Гали. *Михаил --- назланып тормады: --- йомшак кына тамак кырды да зәгыйфь, ләкин сөйкемле тенор белән җырлый башлады.* Ф. Әмирхан.

НАЗЛАУ *ф.* Иркәләү, кадерләү. *Җиңгинең ана булып сөяргә, назларга үзенең тупырчык кебек берсеннән-берсе матур балалары бар иде.* Г. Галиев. *Күзләреңнән күз алмыйча, Назлап йоклатыр идем.* Ә. Ерикәй. *Назлый безнең яңа юлдашны Ак йолдызлар, күктә уйнашып.* Ф. Бурнаш.

НАЗЛЫ *с.* 1. Иркә.— *Нәфисә җаным, назлы кызым, күз нурым, кайгырма, иртән генә булсын, мин үзем сине барып китерәм.* Ш. Камал.

2. Иркәләнүне, назлануны белдергән; ягымлылыкны, йомшаклыкны чагылдырган (караш, сүз һ. б. ш. турында). [*Газинурның*] *кулларында Миңнурый кулларының җылысы бетмәгән, колакларында аның шелтәле дә, үпкәле дә, назлы да тавышы яңгырый.* Г. Әпсәләмов. *Аля берничә назлы сүзләрдән соң үзенең авылда бик күп торса унбиш көн торасы икәнен сөйләде.* Ф. Әмирхан. | *рәв. мәгъ. Һәрвакыттагыча назлы көлә-көлә, Гөлчәһрә йөгереп узды.* Г. Гобәй.

3. Нәзберек, талымчан. *Назлы назланып торганчы, кыю ашап туйган.* Мәкаль. [*Алмачуар*] *электән дә ашауга бик назлы иде.* Г. Ибраһимов.

4. Назланучан, кыстатучан, ялындыручан. *Шулай инде ул, җырчылар, уенчылар һәрвакытта назлы булалар алар.* М. Гали.

НАЗЛЫЛЫК *и.* Иркә булу, назлы булу сыйфаты.

НАЗЫЙР *и. иск.* 1. Иске мәдрәсәләрдә шәкертләрне күзәтеп, тикшереп торучы. [*Җиһангир Гайфигә:*] *Сез — мөгаллим, сезнең вазифа — укытмак. Әмма коридорда „Марсельеза“ җырлауга каршы бәйләнеп йөрү сезнең эш түгел. Моны назыйр карар.* Г. Ибраһимов.

2. Мөдир, идарәдә җитәкчелек итүче. *Назыйр авыл яшьләрен ипкә китерде.* М. Фәйзи.

НАЗЫМ *и. иск.* Шигырь, шигъри төзелеш. [*Ул*] *шигырьләрендә шул китаплардагы назым төзелеше формасын саклап, алар кебек билгеле бер көйгә салып укыла торган революцион эчтәлекле тезмә әсәрләр барлыкка китерде.* М. Гали. [*Әсәрнең*] *назымы гаять җиңел булу өстенә, тасвирлары да гаять шагыйранәдер.* Г. Камал.

НАЗЫМЧЫ *и. иск.* Шагыйрь. *Нәшрият 1908 елларда алып Г. Г. Рәшиди имзасы белән язган бер назымчының үрчемле „иҗадын“ бастырып килде.* И. Рәмиев.

НАИБ *и. иск. кит.* 1. Ислам дине таралган кайбер Көнчыгыш илләрендә берәр башлыкның яисә руханиның ярдәмчесе, урынбасары. [*Шамил өлкәләрнең*] *башлыгы итеп узденнарның баерак катлавыннан чыккан иң якын ярдәмчеләрен — наибларны куйган.* СССР тарихы.

2. Нинди дә булса урынга, чинга яки членлыкка кандидат. *„Ялкау“ комитеты төзедек: алты хакыйкый әгъза, дүрт наиб сайладык.* Г. Ибраһимов.

НАИБЛЫК *и. иск. кит.* Өлкә. *Үз властендагы бөтен территорияне Шамил --- наиблыкларга бүлгән.* СССР тарихы.

НАЙ *и. муз.* Камыштан ясалган курай (үзбәкләрдә).

НАКАЗ *и.* Теләк һәм таләпләр; шуларны белдереп язылган документ. *Сайлаучылар наказы.* □ [*Иванов:*] *Фашистларның муенын астын өскә китереп кайтыгыз! Бездән наказ шул.* А. Әхмәт.

НАКАТ *и.* Махсус җайланма ярдәмендә берәр нәрсәнең өслегенә төшерелгән сурәт. *Һәр квартираның стенасын заманча итеп бизәрбез. Мещаннарча, бронза төсендәге накат туйдырды инде.* Каз. утл. *Монда инде стеналарга да матур накат төшерелмәгән.* С. Рафиков.

НАКАТЛЫ *с.* Накат төшерелгән, накаты булган. *Накатлы стена. Накатлы тукыма.*

НАКЛАДНОЙ *и. махс.* Йөк яки товарны бер урыннан икенче урынга илткәндә бирелә торган кәгазь, документ. *Элеваторга накладнойсыз баруның файдасы юклыгын ул яхшы белә.* А. Гыйләҗев. *Йөкләр санын без Фәһимә белән исәплибез, накладнойлар язабыз.* Ә. Баянов.

НАЛОГ *и.* Дәүләт тарафыннан билгеләнеп, предприятие, учреждение, аерым кешеләр һ. б. түли торган мәҗбүри җыем. *Фронтовик семьялары налогтан*

азат ителә. Г. Гобәй. *Шәмгун карт ул налогны, страховой акчасын һәм башка шуның кебек җыемнарны үз вакытында түләп барырга ярата.* А. Шамов.

НАМ *и. иск.* 1. Исем. *Берсе Габдулла Тукаев җәнапләре тарафыннан назым белән язылган „Алтын этач" нам бер хикәядер.* Г. Камал. || *к.* хак III (5 мәгъ.). *Халыкның дошманны җиңү намына эшләгән тиңдәшсез батырлыклары һәрвакыт күз алдында торып, күңелне кузгатты.* Г. Бәширов. [*Фәхри Мәрьямгә:*] *Үз каршыңда иң кадерле булган нәрсә намыннан үтенәм: син бу казаның сәбәбен хәзергә һичкемгә белдермә.* Г. Ибраһимов.

2. Данлы исем, яхшы ат. — *Мәдрәсәгезнең данын, абруегызның намын пычратмагыз.* Т. Гыйззәт. [*Мидхәт*], *һәрвакыттагы кебек, --- әллә нихәтле купшы сүзләр кулланды, — „Ватан намы өчен!" --- кебек сүзләр белән әтисен исертмәкче булды.* Ф. Хөсни.

НАМАЕШ *и. иск.* Демонстрация, парад. *Барысын вата, барысын җимерә торган шушындый уттан соң безнең солдатлар, намаешка баргандай, байраклар күтәреп атакага киттеләр.* Г. Кутуй.

НАМАЗ *и. дини.* Мөселманнарда: көненә биш мәртәбә үтәлә торган гыйбадәт. *Бер намазга ике азан әйтелми.* Мәкаль. [*Хәят*] *тиз-тиз генә тәһарәт алды һәм аякларын юды, өйдәге фәрештәләргә күрсәтмәс өчен зур бер яулык белән чәчен каплады һәм --- күлмәгенең җиңнәрен бармак очлары гына күренеп калырлык итеп төшерде дә --- намаз укырга тотынды.* Ф. Әмирхан.

Намаз иясе — намаз укуга бирелгән кеше, намазчыл кеше.

НАМАЗЛЫК *и. дини.* Намаз укыганда куллану өчен махсус җәймә. *Абыстай чигеп эшләнгән зур чуар намазлыкны алып бирде.* Г. Ибраһимов. [*Габдулла*] *намазлыгын алып идәнгә җәя һәм ашыгып намаз укый башлый.* Һ. Такташ.

НАМАЗ-НИЯЗ *и. сөйл.* Намаз һ. б. ш. дини йолалар. *Парлы түшәкнең җылысын күптән онытып, намаз-нияз беләнрәк кенә күңел юата башлаган бер тол хатын — Гандәлипне үзенә тартты* [*Шәмсетдин*]. Г. Бәширов. *Әле моңарчы авылда намаз-нияз белән чуалучы юк иде.* К. Нәҗми.

НАМАЗЧЫЛ *с. дини.* Намазны бер дә калдырмый укып баручы. [*Гәүһәрнең*] *апасы бик динле, иске фикерле намазчыл карчык иде.* Г. Ибраһимов.

НАМЕ'СТНИК *и. тар.* 1. Екатерина II вакытында Россиядә бер яки берничә губернаның хәрби начальнигы. *Провинцияләрне наместниклар идарә иткән.* Бор. зам. тар.

2. Патша Россиясенең чик буендагы өлкәләрендә югары дәүләт хокуклары булган, хөкүмәт башлыгы исеменнән идарә итә торган кеше. *Кем ул — бу ят кеше? Каян килгән? Наместникмы берәр? Кенәзме?* Н. Исәнбәт.

НАМЕ'СТНИКЛЫК *и. тар.* Наместник булу, наместник вазифасы.

НАМУС *и.* 1. Үз тәртибеңне, эш-кыланышларыңны бәяләү хисе. [*Тимербулат*] *намусын югалтсынмы Нидидер бер хат өчен?!* М. Җәлил. [*Мисбах*] *яралы булса да, иптәшләреп ташлап китәргә хакы юклыгын, әгәр дә ташлап китсә, намусына гомер буе юып ала алмаслык тап төшерүен бик яхшы аңлады.* Г. Әпсәләмов. || Яхшы исем, абруй, дан. [*Тимергали абзый*] *Акбит нәселенең генә түгел, бөтен тирә-якның данын, намусын иң беренче булып ил-күрше алдында күтәреп чыгучы кеше аның улы — Газиз булырга тиеш дип уйлый иде.* Г. Бәширов. [*Кригер:*] *Ватаныбызның намусын саклау өчен --- немецлар белән сугышабыз.* Т. Гыйззәт.

2. Гыйффәтлелек, сафлык (хатын-кызлар турында). [*Нәфисәнең*] *вөҗданы пакь, аның Газиз истәлегенә яисә үз намусына тузан кадәр генә дә күләгә төшергәне юк!* Г. Бәширов.

Намус белән — тырышып, чын күңелдән, бик яхшы. *Намус белән эшләнгән эш өчен бирелгән бүләктән дә кадерле нәрсә бармыни дөньяда!* Г. Галиев. **Намус белү** — оялу, уңайсызлану. — *Син, исерек килеш, тол хатын өенә килеп кергәнсең. Чәйләр эчеп утырмакчы буласың тагын. Намус белергә кирәк.* Ш. Камал. **Намусы кузгалу (килү)** — уңайсызлану, намуссыну. [*Ибрайның*] *болай да намусы кузгалган булган, кечкенә чанага шактый зур кәрзин беркетте дә, абзарларыннан җылы тирес төяп килеп чыкты.* Г. Гобәй. — *Әй, синең шөребең бушаган, юкка мәшәкатьләнмә! — дигән сүзгә аның намусы килде бугай, ул тагын биергә тырышып карады.* М. Гафури. **Намус саклау (сатмау)** — горурлыкны югалтмау, абруйга, дәрәҗәгә тап төшерә торган эш эшләмәү.

НАМУСЛАНУ *ф.* Берәр эш-хәрәкәтне үтәргә (башкарырга) намус кушмау, намус каршы килү. *Мин хәзер сине „сөеклем!" — дип хитап кылырга намусланамын.* М. Гафури. || Оялу, уңайсызлану. [*Кыз*] *быелгы җәйдә авылда да эшләмәде, райүзәктәге детсадка барып кергән. Биредә намусланганлыр инде, кешедән уңайсызланганлыр.* Р. Төхфәтуллин.

НАМУСЛЫ *с.* Намусы булган; гадел. *Эш мәйданы давыл булып гөрләгәндә, Намуслы кыз эштән читтә кала алырмы?* К. Тинчурин. *Ул намуслы хат ташучы, ул данлыклы районда.* М. Җәлил. || Турылыкны, гаделлекне белдергән; турылыклы. *Сугышчылар, [Газинурның] батыр һәм намуслы йөзенә карап, игътибар белән тыңлап утыралар.* Г. Әпсәләмов. *Фәтхинең --- Мәдинәгә карата намуслы, саф мәхәббәт мөнәсәбәтендә булуы Мәдинәнең йөрәгендә аеруча якты эз калдырды.* Ш. Камал. || Кемнең дә булса үз вазифасына, хезмәтенә һ. б. ш. намус белән караугa нигезләнгән. *Тормышның ләззәте, матурлыгы намуслы хезмәт белән икән.* А. Шамов. | *рәв. мәгъ. Безнең колхозларыбыз һәм совхозларыбыз да халыкны һәм Кызыл Армияне азык белән, промышленностебызны чимал белән намуслы һәм төгәл тәэмин итәләр.* Г. Бәширов.

НАМУСЛЫЛЫК *и.* Намуслы булу сыйфаты. [*Каюм конспект төзүне*], *көндезен эшләп шактый нык арыган булуына карамастан, бик чыдам һәм бик күркәм намуслылык белән эшләде.* Ш. Камал. *Миңнур картка* [*улларының*] *намуслылыклары, батырлыклары турында --- язылган кәгазьләр генә килде.* А. Шамов.

НАМУССЫЗ *с.* Намусы булмаган, вөҗдансыз; оятсыз. *Бәлки кайбер намуссызлар* [*хатны*] *„Ник соң ачмый!" — диярләр.* М. Җәлил. [*Фәридә Исламның*] *ялганчы икәнлеген, намуссыз икәнлеген аңлагандай булды.* Н. Фәттах.

НАМУССЫЗЛАНУ *ф.* 1. Намусны югалту, намуссызга әйләнү.

2. Берәрсенә карата намуссызлык эшләү, гаделсезлек күрсәтү.

НАМУССЫЗЛЫК *и.* 1. Намуссыз булу сыйфаты. [*Гали*] *Зәйнәпне ташлауны намуссызлык, вөҗдансызлык дип белми дә башлады.* М. Гафури.

2. Оятсызлык.

НАМУССЫНУ *ф. сөйл.* Оялу, уңайсызлану, кыймау.

НАМӘ *и. иск.* 1. Хат, записка. *Бәнем шушы хатыма каршы кош теледәй намә күндерсәң, үзеңне күргән кебек булыр идем.* Т. Гыйззәт.

2. Кушма сүзләрдә „язу" (3 мәгъ.), „язулы кәгазь" мәгънәсендәге икенче кисәк, мәсәлән: шәһадәтнамә, таныкнамә.

НА'МӘГЪЛҮМ *с. иск. кит.* Билгесез, билгеле булмаган, мәгълүм түгел. *Бу кара киемле намәгълүм адәм хан кызы Фатыйма иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Кич --- шикле китаплар һәм прокламацияләр таратып йөргән намәгълүм бер кешенең кулга әлгүе --- кебек хәбәрләр сөйләнде.* М. Гафури.

НАМӘХРӘМ *и. иск.* 1. Чит, ят кеше, мөселман хатын-кызлары качарга, күренмәскә тиешле ир кеше. *Монда чыккач, Хәят та иркенләп утыра ала башлады, чөнки намәхрәмнәр күренмиләр иде.* Ф. Әмирхан.

2. Шәригать өйрәтүенчә, чит ир-атка күренергә ярамаган, хәрам саналган хатын-кыз. [*Зыя һәм Мәрьямнең, 13—14 яшьләр тирәсендә булса кирәк, „сез намәхрәмнәрсез“ дип аердылар.* Г. Ибраһимов.

НАМӘХРӘМЛЕК *и. иск.* Намәхрәм булу хәле. *Бу эшем бер алдашу, искедән калган намәхрәмлек тойгысын муллаларча итеп көчсезләндерергә азаплану --- һәм бу турыда үземне акларга маташу иде.* М. Галәү.

НАНАЙ *и.* Амур елгасының түбән агымында яшәүче халык һәм шул халыкның бер кешесе. || *с. мәгъ.* Шул халыкка мөнәсәбәтле. *Нанай теле.*

НАНДУ *и. зоол.* Көньяк Америкада яшәүче, муены белән башын йон каплаган өч бармаклы тәвә кошы.

НАНЫЙ *и. диал.* Иркәләп әндәшү сүзе. — *Балакаем, наныем, исән-сау кайттыңмы? — дип, Сабир бабай да ике кулын сузды.* Г. Әпсәләмов. [*Мәпә Бикбулатка:*] *Синең костюмыңны да рәтлисе бар, наный.* Н. Исәнбәт.

НАПАЛМ *и. хәрби.* Яндыргыч бомбалар, огнемётлар өчен составында желе сыман бензин булган махсус катнашма.

НАПА'ЛМЛЫ *с.* Напалм тутырылган. *Напалмлы бомба.*

НАПРАВЛЕ'НИЕ *и. сөйл.* Берәр җиргә җибәрү турындагы рәсми кәгазь. [*Рәимә:*] *Кадрия, больницага направление яз.* М. Хәсәнов.

НАР I *и. сөйл.* Бина эчендә тактадан ясалган ятак урын, такта сәке. *Аслы-өсле нарларда берникадәр эшчеләр ятып ял италәр.* Ш. Камал. *Хәтереңдәме, теге икәү нарда йоклаган чаклар?* Һ. Такташ.

НАР II *и. иск.* Ут, ялкын.

НАРАСЫЙ *и.* Бала, кечкенә бала; сабый. *Сәяра, яраксыз эш кылган нарасый кебек, уңайсызланып китте.* Б. Камалов. *Карты, яше, баласы, Булса да ул нарасый, Тигезләнде арасы.* Г. Камал. || *с. мәгъ.* Сабый, кечкенә, бик яшь. *Нарасый балалар төсле бер үксеп-үксеп елыйсым килә.* С. Җәләл. *Өр-яңа дәфтәрләр, Өр-яңа әлифба — Канат ул, бәхет ул Нарасый халыкка* [*балаларга*]. З. Мансур.

НАРАТ *и. бот.* Күркәләре зур булмаган, ылыслы, мәңге яшел агач. *Бары тик наратлар, чыршылар һәм ак чыршылар гына үзләренең яшел ылысларын коймыйлар, алар җәй көннәрендәгечә бизәнеп-ясанып утыралар.* Г. Әпсәләмов. || Төзү материалы буларак шул агач. *Йортлар нараттан була.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Нарат агачыннан эшләнгән, ясалган. *Колгага нарат такталардан эшләнгән оя куелган.* А. Алиш.

Нарат гөмбәсе *бот.* — ылыслы һәм катнаш урманнарда үсә торган, эшләпәсе аксыл яки куе коңгырт төстәге калын саплы гөмбә; *русчасы:* груздь. *Нарат гөмбәсен, кызыл гөмбәне --- 5—6 сәгать салкын суга салып торырга --- кирәк.* Йорт эшләре. **Нарат күркәсе** — кабырчык каплаган, гадәттә түгәрәк яки йомырка сыман чәчәклек. [*Яз көне*] *наратта ачык яшел һәм кызгылт төстә нарат күркәләрен табуы җиңел була.* Ботаника. **Нарат сагызы** — нараттан чыга торган сагыз, чәер. *Һавадан үлән исе, каен җиләге исе, нарат сагызы исе аңкый.* А. Расих. **Нарат үләне** — *к.* наратбаш. **Нарат җиләге** — ылыслы һәм катнаш урманнарда үсә торган, мәңге яшел яфраклы, аксыл ал төстәге чәчәк ата торган куак; җиләге ачык кызыл төстә, ашарга яраклы; *русчасы:* брусника. *Иксез-чиксез сазлыкларда бу айда кара җиләк, нарат җиләге --- өлгерә.* Э. Касыймов.

◇ **Нарат сагызы (чәере) булу** — бәйләнү, аптырату.

НАРАТБАШ *и. бот.* Споралы үлән үсемлекләрнең югары төзелешле төре; *русчасы:* хвощ. *Наратбашлар кечкенә генә яшел чыршы рәвешендә булалар. Аларның сабаклары вертикаль рәвештә югарыга таба үсә.* Ботаника.

НАРАТЛЫК *и.* Нарат күп үскән урын, нарат урманы. *Сагындым соң эскерт таулардагы Наратлыкның бөдрә яшелен.* Ш. Маннур.

НАРГИЛӘ *и. иск.* Төтенен су аркылы үткәрә торган тәмәке тарткыч. *Аның наргилә белән исерә төшкән башында әллә нинди хыялый сурәтләр, хыялый рәхәтләр туалар.* Ф. Әмирхан.

НАРЗАН *и.* Углекислый газлы минераль су (дәвалану өчен кулланыла). *Әллә ничек кенә таныштык без, Әллә нинди сүздән башладык. Һава суладык без. Җыр тыңладык. Нарзан эчтек, Карбыз ашадык.* Э. Ерикәй. *Менә шушы нарзан чишмәсеннән генә дә көн саен егерме миллион литр чамасы су агызалар.* Г. Мөхәммәтшин.

НАРКОЗ *и. мед.* 1. Махсус дару ярдәмендә әгъзаның сиземләвен ясалма рәвештә туктату яки кешене бернәрсә дә сизмәслек хәлгә китереп йоклату. *Гомуми наркоз астында тирән йокыга талган авыру өстенә хирург иелгән.* Соц. Тат. *Врачлар аңа операцияне ни өчендер --- наркозсыз гына ясыйлар.* Каз. утл.

2. Медицинада авыртуны бетерү һәм йоклату өчен кулланыла торган матдә. *Наркоз биреп йоклату. Наркоз җибәрү.*

НАРКОМ *и. тар.* Халык комиссары.

НАРКОМАН *и. мед.* Наркомания белән җәфаланучы кеше.

НАРКОМА'НИЯ *и. мед.* Наркотиклар белән артык мавыгудан, шуларны күп кулланудан гыйбарәт авыру.

НАРКОМАТ *и. тар.* Халык комиссариаты. *Бездә наркоматлар 1921 нче елны түгел, революция башында ук төзелде.* М. Җәлил.

НАРКО'ТИК *и. мед.* 1. Медицинада авыртуны басу һәм йоклату өчен кулланыла торган матдә. || Әфьюн, морфий, героин һ. б. ш. кебек исертә, мингерәүләтә торган матдә. *Җинаятьчеләр документларын, алтынны, --- тыелган наркотикларны кайда гына яшерсәләр дә, старшина аларны бер карау белән таба.* Соц. Тат.

2. *сөйл. к.* наркоман.

НАРО'ДНИК *и. тар.* Народниклык тарафдары. *Народникларның демократлыгы шунда ки, алар хәзерге вакытта җирбиләүчелектәге бөтен имтиязларны бетерергә омтылалар.* Г. Нигъмәти. *Бу, билгеле, яшерен түгәрәк түгел, монда народниклар фәлсәфәсе дә, марксистлар фәлсәфәсе дә яңгырамый.* Г. Әпсәләмов.

НАРО'ДНИКЛЫК *и. тар.* Революцион көрәштә эшчеләр сыйныфының җитәкчелек ролен инкяр итеп, крестьяннар хәрәкәтен яклаган, XIX йөзнең икенче ярты сында барлыкка килгән вак буржуаз ижтимагый агым. *70 нче еллар народниклыгы Россиядәге революцион хәрәкәт үсешендә әһәмиятле роль уйнады.* КПСС тарихы.

НА'РТА *и.* Төньякта болан һәм этләр җигеп йөрү өчен махсус эшләнгән озынча тар чана. *Ишек төбенә пар болан җиккән нарта килеп туктады.* Каз. утл.

НАРЯД *и.* 1. Берәр эшне үтәр өчен язма рәвештә яки телдән бирелгән боерык, күрсәтмә. *Шиһаби абзый --- һәрбер килгән бригадирның рапортын тыңлап, аларга иртәнге өш өчен нарядлар бирә башлады.* М. Гали. [*Мирсәет Гафурга:*] *Бүген кич правлениегә наряд алырга кил.* Р. Ишморат.

2. Эшнең характеры һәм күләме күрсәтелгән, эш хакы түләү өчен нигез булып торган документ. || Шулай ук товар, төрле йөк һ. б. ш. алу, җибәрү өчен бирелгән документ. *Москва наряды белән каяндыр „Заготзерноның" яңа салынып яткан складлары өчен калай килә.* Ә. Еники.

3. *хәрби.* Хәрби хезмәткәр үти торган берәр төрле задание, эш; дежур тору. *Занятиеләрдән, нарядлардан соң ни бары 3—4 сәгать кенә вакыт кала.* М. Җәлил.—*Көчкә наряд белән котылдым, трибуналга бирүләре дә мөмкин иде.* Г. Әпсәләмов.

4. *хәрби.* Шундый заданиене үтәүче төркем яки хәрби хезмәткәрләр подразделениесе. *Бердәнбер тыныч урынны көчәйтелгән полиция наряды камап алган иде.* А. Расих.

НАРЯДЧЫ *и. сөйл.* Кешеләрне эшкә билгеләүче, эшне оештыручы кеше.

НАРӘСИДӘ *и. иск. кит. к.* нарасый. *Бәхетле нарәсидә! Тар бишек тә киң әле аңар.* Г. Тукай.

НАС *и. к.* насвай.

НАСВАЙ *и.* Тел астына сала торган тәмәке (гадәттә Урта Азия республикаларында кулланыла). *Егетләрнең өченчесе --- бер чеметемдәй насвай алып, --- аскы ирене белән тешләре арасына салып җибәрде.* М. Гафури.

НАСВАЙЧЫ *и.* 1. Насвай тартучы.

2. Насвай сатучы.

НАСОС *и.* Сыеклык һәм газларны суырту өчен кулланыла торган җайланма. *Газинур белән Һашим килеп җиткәндә, сарайның түбәсе яна, Гафиятулла бабай насостан су сиптерә иде.* Г. Әпсәләмов. *Эшелонның паровозлары --- елгадан насос белән су алалар.* Ш. Усманов.

НАСТРОЕ'НИЕ *и. сөйл.* 1. Кәеф, рухи халәт. *Кунакларның килгән берсе берәр төрле мәзәкле сүз белән каршы алына, шулай итеп күңелле настроение тудырырга тырышыла иде.* Ш. Камал. *Әлеге көндезге әшәке настроение* [*Мостафада*] *юк иде инде.* Ә. Еники. || Нәрсәгә дә булса мөнәсәбәт, гомуми караш. *Настроение шактый кызу. Нәрсәдер көтәләр.* К. Нәҗми.

2. Кешенең фикере, уйларының юнәлеше; омтылыш. *Җәмәгатьчелек настроениесе.* □ *Әсәрдә Әхмәди шактый аңлы һәм революцион настроениеле эшче итеп бирелә.* М. Гали.

НАСТУ'РЦИЯ *и. бот.* Әфлисун төсендәге әрә чәчәкле үләнчел декоратив үсемлек.

НАСЫЙП *и. иск.* 1. Язмыш, күрәчәк; кешегә тигән өлеш, тәкъдир. [*Сафый:*] *Насыйптан артык бер нәрсә дә булмый.* Ф. Әмирхан. || Дин өйрәтүенчә: алла бәхет бүлгәндә кемнең дә булса өлешенә чыгу, өлешенә тию турында. *Бу хатынга бирелгән моң белән музыка дөньяда тагы кемгә дә булса насыйпмы? — дип хәйран булдым.* Г. Ибраһимов.

2. Мөмкинлек, җай чыгу, туры килү. *Данлыклы, шат илнең җырын Җырлау насыйп бүген безгә.* М. Җәлил.

Насыйп булса (итсә) *кер. сүз* — боерган булса; язган булса, алла боерса, ходай язса (теләк теләгәндә, берәр нәрсәне өмет иткәндә яисә ни дә булса эшләргә планлаштырганда әйтелә торган сүз). [*Лалә.*] *Көймә белән шомыртка барабыз, насыйп булса:* М. Фәйзи. **Насыйп булу** — туры килү, әләгү, җай чыгу, берәр нәрсәгә ирешү. *Ләкин ул төнне дә һәм аннан соңгы бик күп төннәрдә дә Дәүләтшингә тыныч йокы насыйп булмый.* И. Гази. [*Искәндәр:*] *Хәтерлим, аңар бу чынаяк белән бер йотым су да эчәргә насыйп булмады, минем кулдан --- алганда төшереп ватты.* Г. Гобәй. **Насыйп итсен (кылсын)** — теләк сүзе буларак йөри: алла язсын, туры килсен, тормышка ашсын. *Исәнлектә күрешергә насыйп итсен, — дип миңа кул бирде* [*Харрас*]. Ә. Айдар. [*Әни Хәдичә:*] *Тигез-рәхәт гомер итәргә насыйп итсен.* А. Шамов. **Насыйбы чыгу** — дини: язмыш тарафыннан билгеләнгән, өлешеңә тигән әйбернең кулыңа керүе яки берәр кеше белән тормышыңны бәйләү турында. — *Син яшь кеше, бер насыйбы чыгар, гомер буе атаң йортында ятмассың.* Г. Бәширов.

НА'СЫПЬ *и. сөйл.* Балчык, туфрак һ. б. өеп ясалган биек урын, өймә. *Күз күреме җитәрлек ераклыкка сузылган үзәнлекне урталай бүлеп, биек итеп насыпь өелгән.* М. Хәсәнов.

НАТР *и. хим.* Натрийның искергән атамасы. *Зәһәр натр.*

НА'ТРИЙ *и. хим.* Аксыл көмеш сыман төстәге йомшак металл.

НАТУ'РА *и. махс.* 1. Рәсем ясау, кинога төшерү, әсәр язу һ. б. өчен табигый үрнәк. *Сәгыйть әфәнде --- әсәренең сюжетын „мәдрәсәи Хөсәения"дән алып, хәтта геройларын да шундагы хәлфәләр вә мөдирләрдән, ягъни натурадан алып язгандыр.* Ф. Әмирхан.

2. Холык, табигать, характер. *Ифрат үзенең төгәл натурасы белән --- инструкторның хөрмәтен яулап алган иде.* А. Расих.

НАТУ'РАЛАТА: натуралата түләү — акча урынына товар, азык-төлек һ. б. белән түләү.

НАТУРАЛИЗМ *и. әд.* Әдәбият һәм сәнгатьтә XIX йөзнең 60 нчы елларында барлыкка килгән, тормышның бөтен ваклыкларын күрсәтеп, иҗтимагый үсеш законнары белән кызыксынмаган буржуаз агым. *Мин натурализмга каршы, тормыш кисәкләрен шул көенчә, фотографияләп дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк.* Г. Ибраһимов.

НАТУРАЛИСТ *и.* 1. Табигатьне өйрәнү белән шөгыльләнүче. *Яшь натуралистлар түгәрәге.*

2. Натурализм тарафдары.

НАТУРАЛИ'СТИК *с.* 1. Натурализмга караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Натуралистик юнәлеш. Натуралистик әдәбият.*

2. Көнкүреш ваклыкларына игътибар итүдән гыйбарәт булган, чынбарлыкны тасвирлау, сурәтләүдә гомумиләштерү булмаган. *Икенче актта Закир белән Галимәне сәхнәдә чыбык белән суктыру артык шикелле. Бу — бик натуралистик булып килеп чыга.* М. Җәлил.

Натуралистик мәктәп — XIX йөзнең 30—40 нчы елларындагы рус әдәбиятында алдынгы реалистик агым (әдәби әсәрләрдә әһәмиятле иҗтимагый әхтәлекне бирү, чынбарлыкны дөрес реалистик сурәтләү, самодержавиене, крепостной стройны тәнкыйть итү, тормышны бизәкләп, бозып сурәтләүгә каршы көрәшне үз эченә ала).

НАТУРАЛЬ *с.* Чын, табигый булган; киресе: ясалма. *Натураль мех.* □ *Натураль ефәк тукымаларны чылатмыйлар, бәлки дымлы чүпрәк аркылы үтүкиләр.* Соц. Тат.

Натураль хуҗалык — җитештергән продуктларын сатмыйча, аларны үз ихтыяҗлары өчен генә куллана торган хуҗалык. *Феодалның хуҗалыгы үзенең нигезендә натураль хуҗалык булган.* Политэкономия.

НАТУРФИЛО'СОФ *и. махс.* Натурфилософия тарафдары.

НАТУРФИЛОСО'ФИЯ *и. махс.* Тәжрибә фәннәре тикшерүләренә түгел, бәлки коры фикер йөртүгә нигезләнеп кенә табигать турында тәгълимат бирергә тырышкан философия.

НАТУ'РЩИК, НАТУ'РЩИЦА *и.* Рәссам яки скульптор сурәт яисә сын ясаганда аның каршында күчергеч булып торучы кеше. [*Морат Мәрьямгә:*] *Натурщица булып эшлә: буй-сының, килеш-килбәтең менә дигән.* М. Маликова.

НАТЮРМОРТ *и.* Нинди дә булса предметлар җыелмасы төшерелгән картина яки рәсем; шул предметлар үзләре.

НАУ'ШНИК *и. сөйл.* Радио, телефон кебек аппаратларда колакка киелә яки куела торган тыңлау приборы. *Партерда махсус тәрҗемә ешитырылган. Колагыңа наушник ал да тыңла.* А. Гыйләҗев.

НАФТАЛИН *и.* Техникада, шулай ук йон, мех әйберләрен көядән саклау өчен кулланыла торган бик көчле исле ак кристалл матдә. [*Бибиҗамал*] *сандыктагы кара йон күлмәген алып ишек алдына чыкты да нафталиннан тазартты.* Ш. Хөсәенов.

НАФТАЛИНЛАУ *ф.* Нафталин сибү, нафталин кую. *Киемнәрне нафталинлап кую.*

НАХАК *с.* **1.** Бер нәрсәгә дә нигезләнмәгән, реаль булмаган, дәлилләнмәгән. *Әткәй кебек зур, таза, баһадир, сылу абзамны нахак бәлагә эләктерделәр.* Г. Ибраһимов. *Кызы кебек якын күргән киленененең үз йортыннан нахак сүз аркасында мыскылланып китүен карт авыр кичерде.* Г. Бәширов.

2. *рәв.* Нигезсез, хаксыз, урынсыз. *Юк, нишләп нахак сөйләсеннәр, бик дөресен әйттеләр.* Ә. Еники. *Берәр малай кыйнап кайтарса яки әнисеннән нахакка әләксә, Хәлим ике йорт арасындагы коймага башын куя иде дә үксеп елый иде.* Г. Гобәй.

НАХИ'МОВЧЫ *и.* Нахимов училищесында тәрбияләнүче.

НАЦИЗМ *и. полит.* Немец фашизмы.

НАЦИОНАЛИЗА'ЦИЯ *и. полит.* Предприятие, җир, производство тармаклары кебек нәрсәләрне хосусый милектән дәүләт милкенә әверелдерү. *Җиргә национализация ясау. Промышленностька национализация ясау.*

НАЦИОНАЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Национализация үткәрү. *Төп транспорт һәм элемтә средстволары национализацияләнде.* Чит ил. экон. геогр.

НАЦИСТ *и.* Нацизм яклы кеше, немец фашистлары партиясе члены. *Шейман үзенең докладында нацистларның һичшиксез җиңеләчәгә турында ышандырырлык итеп сөйләде.* Каз. утл. *Илбасар палачлар, нацистлар, фашистлар, ерткычлар оясы Пыр тузды, таралды.* Б. Рәхмәт.

НАЧА'ЛЬНИК *и.* Нәрсәгә яки нәрсәне дә булса житәкчелек итүче, эш башында торучы кеше; башлык; рәсми җитәкче. *Китүчеләрне кызыл почмакка җыеп, аларга госпиталь начальнигының приказын укыдылар.* Г. Әпсәләмов. *Дхмәт эрләү цехының начальнигы белән танышкач, аңардан Рамазанова белән күрештерүне сорады.* Г. Минский.

НАЧА'ЛЬНИКЛЫК *и.* Начальник булу, начальник вазифасы.

НАЧА'ЛЬСТВО *и. сөйл.* **1.** *җый.* Начальниклар, башлыклар, эш башында торучылар. *Җамали әле --- казарма тормышы белән нык сугарылмаган, начальство белән эш итәргә өйрәнмәгән --- иде.* М. Гали.

2. *сөйл.* Начальник. [*Сафия Зарифка:*] *Сүзең ялган булмаган, чынлап та зур начальство белән дуслыгың бар икән.* Ш. Камал.

НАЧАР *с.* **1.** Кире сыйфатлары яки үзлекләре булган; куелган таләпләргә туры килми торган, түбән сыйфатлы; түбән бәя бирелә торган; *киресе:* яхшы. *Начар кием. Начар ял.* □ *Фәүзия җиңги, начар гына ике сыерыннан савып алган сөтен мөмкин кадәр кысып тотып, байтак май әзерләде.* М. Гафури. | Сәнгать әсәрләре турында. *Начар фильм. Начар музыка.* || Күңелсез, әйбәт булмаган. *Начар нәтиҗә. Начар фикер.* □ *— Авылдан бик начар хәбәр белән килделәр.* Т. Гыйззәт. | Һава турында. *Начар җәй. Начар һава.* □ *Яңгыр булса, ай-яй көн начар, кебек сүзләр әйтелә.* Ш. Камал. || Үз эшендә тәжрибәсе булмаган, оста булмаган, булдыксыз (кеше турында). *Начар җитәкче. Начар тегүче. Начар укытучы.* □ *Камил әфәнде белән бергә җырлый торган Фатыйма ханым—тәнкыйтьтән түбән дәрәҗәдә начар җырчы.* Ф. Әмирхан. || *рәв. мәгъ.* Тиешенчә, таләп ителгәнчә, кирәгенчә түгел. *Начар киенү. Начар күрү.* □ *Сәлимне Ильяс абый бик начар каршы алды.* Г. Гобәй. *Мисбах тирә-якта нәрсәләр барганын начар аңлый башлады.* Г. Әпсәләмов.

2. Мораль яктан түбән; кире сыйфатлары булган (кеше турында). *Башлыгыбыз --- начар кеше түгел иде.* Ш. Камал. *— Сессиядә бит Нургали абыйны начар кеше дип әйтүче булмады.* Ә. Еники. || Тупас, вульгар (үз-үзен тотышы, зәвыгы һ. б. белән). *Начар характер. Начар мөгамәлә.* □ [*Зиннәт*] *үзе бер бөртек тә үзгәрмәде, ә шулай да аны бөтен ишек алдында начар һәм усал малай дип йөри башладылар.* А. Шамов.

3. Авыр тәэсир калдыра торган; күңелсез тәэсир итә торган (кәеф, төш һ. б.). *— Бүген Хәмит турында начар төш күрдем мин.* Р. Ишморат. | *хәб. функ. Бүген янгыннан соң картның кәефе аеруча начар иде.* Г. Әпсәләмов. || Әдәпсез, әшәке (сүзләр турында). *Бер яктан төрле начар сүзләр белән Җиһанша абый тирги, кыйный.* К. Тинчурин. *Уртанчы киленең алай начар теле дә юк, холкы да бик әйбәт.* Г. Ибраһимов. || Уңай булмаган (җавап, сүз һ. б.). *— Мин сездән мондый начар сүз ишетермен дип килмәгән идем.* Г. Камал. | *и. мәгъ. Һәр нәрсәгә исем китеп йөри, Беренче кат күргән шикелле, Һәр яхшыга әзрәк сөенеп китәм, Һәр начарга „сытам үтемне“.* Ш. Маннур.

4. Авыруның хәле өметсез булу турында. [*Врач:*] *Әниегезнең хәле начар, — диде.* А. Шамов.

5. Сан, күләм ягыннан җитәрлек булмаган, зур булмаган, аз. *Начар түләү. Начар үсеш.* | *хәб. функ. Җиһангир тыштан яхшы киенеп йөрсә дә, тамак ягы начар, күп вакыт икмәк-су белән яши иде.* Г. Ибраһимов. *Үләннең үсүе начар. Ул бөтенләй кибү, кору алдында тора.* Ш. Камал.

6. *махс. к.* икеле (3 мәгъ.). [*Шабановның*] *ике предметтан начар билгесе бар.* Т. Гыйззәт.

◇ **Начар юлдан китү** — бозыклыкка бирелү.

НАЧАРАЮ *ф. сөйл. к.* начарлану. *Гөлҗамал, йөгереп кергән Хәлимне күрүгә: „Әллә әтиең начарайдымы?“ — дип сорады.* И. Гази.

НАЧАРЛАНУ *ф.* **1.** Начар хәлгә җитү, бозылу. *Һава ифрат начарланган, тын алгысыз эссе иде.* Ш. Камал. *Юл, начарланганнан-начарлана барып, чиге күренмәгән баткаклыкка әверелде.* К. Нәҗми.

2. Берәр нәрсәнең әлеккегә караганда начар якка үзгәрүе. *— Хәтереңнең начарланган, күрәм.* К. Тинчурин. *Бигрәк көтелмәгәндә Гыйззәт абзый үлеп китеп, Хәйретдин яшь калгач, аларның тормышлары тагын да начарланып китте.* М. Гали.

3. Бик авыр хәлгә төшү, үлем хәленә җитү (авыру турында). *Бер авыруның хәле начарланган, профессор операция ясарга булган.* Т. Гыйззәт.

НАЧАРЛАТУ *ф.* 1. Нәрсәне дә булса (мәсәлән, ашауны) әлеккегә караганда кимету.

2. Начар якка үзгәртү. *Үзенең мөнәсәбәтен начарлату.*

НАЧАРЛЫК *и.* 1. Начар булу, яраксыз булу. *Сер тотмауның начарлыгын исеңдә тот син, кирәксезне һич сөйләмә, телең тик торсын!* А. Алиш. *Юлларның начарлыгын әйтергә дә юк.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр кешегә эшләнә торган эшәкелек, усаллык, явызлык. — *Мин бит аңа бернинди дә начарлык эшләмәдем.* А. Әхмәт. [*Наилә:*] *Кешеләргә, дәүләткә әз генә булса да начарлык эшләгәнен күрмәдем* [*этиненең*]. Р. Ишморат.

3. Хупланмый торган эш, әдәпсезлек. *Зиннәт - - - гафу үтенмәгәнлеген һәм тагын бер начарлык эшләгәнен шунда гына сизеп алды.* А. Шамов.

НАШАТЫРЬ *и.* 1. Хлорлы аммоний (техника һәм медицинада кулланыла торган ак кристалл матдә).

2. *сөйл. к.* нашатырь спирты. *Ләкин* [*Рамизның*] *борынын ярып кергән нашатырь исе аны кабат-кабат аңына китерде.* Каз. утл.

Нашатырь спирты — аммиакның судагы эремәсе, төссез, үтә күренмәле, бик нык исле сыеклык (медицинада кулланыла). *Уколлар ясагач, - - - нашатырь спирты иснәтә торгач, Бибиҗамал апа һушына килде.* Ш. Хөсәенов.

НАШИ'ВКА *и. хәрби.* Хәрби званиеләрне аеру өчен якага, җиңгә һ. б. тегелә торган билге. *Сары чәчле, нашивкалы солдат - - - чалкан егылды.* Г. Бәширов. || Яраланган яки сроктан тыш хезмәт иткән өчен хәрбиләргә бирелә торган почетлы билге.

НАШИР *и. к.* нәшир. *Каушап, өмет катнаш курку белән нашир әфәндегә барып, әсәреңне бирәсең.* Г. Ибраһимов. — *Мин сезгә наширларның адресын биргән идем шикелле.* Т. Гыйззәт.

НАЯН *с.* 1. Шук, уенчак, шаян. *Әй шаян кыз, ай наян кыз, матур икәнсең, Таң атканда юлга чыгып кемне көтәсең?* Ә. Ерикәй. — *Һидият ул ифрат наян, Мостафа да шундыйрак.* Ш. Камал. || Шаянлыкны белдергән. [*Нәфисәнең*] *ирен кырыйларында наян елмаю бизәге эленеп тора, күзләрендә моңсу бер куаныч балкый иде.* Г. Бәширов.

2. *сөйл.* Хәйләкәр, мут. — *Бер заман әллә нәрсә шарт итте. Борылып карасак, градусник икән. 36 дан күтәрелмәгәч, боткага тыккан булган, наян!* Г. Гобәй.

НАЯНЛАНУ *ф.* 1. Шаяру, шуклану, шаянлану. *Авылга кайтып җитәрәк,* [*Йөзлебикә*] *тагын наянлана башлады.* Г. Бәширов. | *күч. Кояш нуры артык наянлана башласа, агач күләгәсенә утырып ял итәсең.* М. Максуд.

2. *сөйл.* Кылану, хәйләләү. *Нәгыйм абзый һаман үз сүзен кабатлады: „Бәйләмичә калдырып кара, хәзер торып китә ул, юри наянланып кына ята“, — диде.* Ш. Камал.

НАЯНЛЫК *и.* 1. Шаянлык, шуклык, уенчаклык. [*Балалар*] *уен барганда өйгә кереп-чыгып, егетләр янына килеп сугып китү, бүрекләр бәреп төшерү кебек наянлыклар эшләп йөриләр.* М. Фәйзи. [*Мәдинәнең*] *шуклык, наянлык сирпегән күзләре* [*Хәбиргә*] *текәлде.* Ш. Хөсәенов.

2. Кыланчыклык, хәйләкәрлек.

НЕВРАЛГИ'Я *и. мед.* Нерв һәм аның тышчасының ялкынсынуы яки зарарлануы аркасында барлыкка килгән һәм хәрәкәт вакытында үзен сиздерә торган авырту.

НЕВРАСТЕ'НИК *и. мед.* Неврастения белән авыручы кеше.

НЕВРАСТЕ'НИЯ *и. мед.* Нерв системасының бик нык какшавы (кеше тиз арый, ярсып китә, башы авырта һ. б.).

НЕВРИТ *и. мед.* Нерв ялкынсынуы һәм аның бәрелү, салкын тию яки инфекция эләгү аркасында тагын да көчәеп китүе.

НЕВРОЗ *и. мед.* Үзәк нерв системасының какшавы аркасында килеп чыккан авыру (эчке органнар функциясенең эшчәнлеге кими, матдәләр алмашы бозыла һ. б.). *Йөрәк неврозы. Ашказаны неврозы.*

НЕВРО'ЛОГ *и. мед.* Неврология белгече — врач.

НЕВРОЛО'ГИЯ *и. мед.* Нерв системасының төзелеше һәм эшчәнлеге турындагы фән.

НЕВРОПАТО'ЛОГ *и. мед.* Невропатология белгече — врач. *Карт невропатолог башта Арслановның зарын, аннары йөрәген тыңлады, тез башларына каккалап-суккалап карады.* Г. Минский.

НЕВРОПАТОЛО'ГИЯ *и. мед.* Нерв системасы авыруларын өйрәнә торган фән.

НЕГАТИВ *и. махс.* Пыяла яки плёнкага төшерелгән кире (ак урынына кара, кара урынына ак булып төшкән) рәсем; шундый рәсем төшерелгән пыяла яки плёнка. *Салих, мавыгып китеп, картлар китергән негативларның барысын да шул ук кичне кәгазьгә төшереп бетерде.* Каз. утл.

НЕГР *и.* Тропик Африканың кара тәнле төп халкы, негроидлар расасы вәкиле.

НЕГРО'ИД: негроид расасы *махс.* — кешелекнең төп расаларыннан берсе булган бөдрә чәчле, кара кучкыл тәнле, киң ямьшек борынлы халык. *Африка халыкларының күпчелеге кара кучкыл тәнле негроид расасына керәләр.* Гомуми биология.

НЕ'ГУС *и.* Эфиопия императоры титулы һәм шул титулга ия булган кеше.

НЕДОИ'МКА *и. сөйл.* Налогның вакытында түләнми калган өлеше. *Карабаш авылында крестьяннар недоимка түләүдән баш тарткannар.* А. Расих.

НЕЙЛОН *и.* 1. Ясалма сүснең бер төре һәм шуңардан эшләнгән тукыма.

2. *с. мәгъ.* Шул тукымадан тегелгән, бәйләнгән. [*Гаязның*] *аягында зәңгәрсу нейлон оекбаш.* Х. Сарьян.

НЕЙРОН *и. мед.* Нерв күзәнәге һәм шуннан төрле якларга таралган җепселләр.

НЕЙРОХИРУРГ *и. мед.* Нейрохирургия белгече — врач. *Врач Николай Сергеевич — оста куллы, үз эшен бик нечкә белүче нейрохирург.* Ф. Яруллин.

НЕЙРОХИРУРГИ'Я *и. мед.* Хирургиянең үзәк һәм периферик нерв системасы авыруларын дәвалау белән шөгыльләнә торган тармагы. — *Нейрохирургия бүлегенә алып килгәч бик пошынган идем, хәзер азрак аңга килдем бугай.* А. Гыйләҗев.

НЕЙТРАЛИЗА'ЦИЯ *и.* Нейтральләшү хәле, нейтральләштерү эше.

НЕЙТРАЛИТЕТ *и. махс.* Халыкара хокукта: сугыш вакытында берәр дәүләтнең сугышка катнашмыйча, сугышучы дәүләтләргә карата битараф позициядә булу хәле; битарафлык.

НЕЙТРАЛЬ *с.* 1. Сугышучы дәүләтләргә карата нейтралитет, битарафлык саклаган, битараф булган.

2. Сугышучы якларның берсенә дә карамаган. *Иран русларның (төньяк) һәм инглизләрнең (көньяк) йогынты сфераларына бүленә, бу сфералар бер-берennән „нейтраль зона“ белән аерылалар.* Яңа тарих.

3. Көрәш, бәхәс һ. б. ш. булганда бер якка да катнашмаучы, бер якны да якламаучы, битараф. *Нейтраль кеше.*

4. *махс.* Организмга файда да, зарар да итми торган (дару, төрле матдәләр һ. б. турында). *Нейтраль дару.*

5. *хим.* Кислота яки селте реакциясе бирми торган. *Нейтраль реакция. Нейтраль эремә.*

НЕЙТРАЛЬЛЕК *и.* Нейтраль булу хәле; битарафлык. *Германия гаскәрләре, Бельгиянең нейтральлеген бозып, Бельгиягә басып керә.* Яңа тарих.

НЕЙТРАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* 1. Халыкара хокукта: сугыш вакытында берәр дәүләтне яки районны сугышучыларның берсе яклы да түгел дип игълан итү, битарафлаштыру. *Дәүләтне нейтральләштерү. Территорияне нейтральләштерү.*

2. *хим.* Селте тәэсирендә эремәнең кислоталык үзлекләрен яки, киресенчә, кислота тәэсирендә селтелек үзлекләрен бетерү. *Эремәне нейтральләштерү.*

НЕЙТРАЛЬЛӘШҮ *ф.* Нейтраль (5 мәгъ.) хәлгә килү. *Аш-суны хәзерләгәндә үк сода нейтральләшеп бетә.* Азат хатын.

НЕЙТРОН *и. физ.* Атом төше составында электр корылмасы булмаган кисәкчә. *Д. Д. Иваненко тәкъдим иткән теория буенча барлык атомнарның да төшләре протоннардан һәм нейтроннардан тора.* Химия.

НЕКРОЛОГ *и.* Үлгән кешенең тормышы һәм эшчәнлеге турында язылган мәкалә. *Некролог язу.* □ [*Лотфулла*] *газетада басылган некрологларны моңарчы укымаска тырыша.* Г. Ахунов.

НЕКРО'ПОЛЬ *и.* 1. Борынгы Көнчыгыш илләрендәге каберлек; зират.

2. Бөек кешеләр күмелгән каберлек.

НЕКТАР *и. бот.* Үсемлекләр бүлеп чыгара торган татлы, баллы сыекча, чәчәк балы. *Алмагач чәчәгенең төбендә баллы сыекча — нектар бүленеп чыга.* Ботаника.

НЕКТАРЛЫК *и. бот.* Чәчәктә нектар бүлеп чыгара торган орган.

НЕ'ЛЬМА *и. зоол.* Сөләйман балыклары семьялыгында исәпләнгән, төньяк елгаларда һәм диңгезләрдә яши торган кыйммәтле балык.

НЕ'МЕЦ *и.* Германиянең төп халкы һәм шул халыкның бер кешесе.— *Безнең бу якка, иптәш Хәйров, нефть эзләп элекке заманда англичаннар да, америкалылар да, немецлар да килгәннәр.* А. Әхмәт. | *с. мәгъ.* Немец халкына мөнәсәбәтле. *Немец теле. Немец әдәбияты.*

НЕ'МЕЦЧА *рәв.* Немец телендә. *Тәрҗемәче нидер немецча әйтте.* Ә. Айдар.

НЕ'МЕЦЧАЛАП *рәв.* Немец телендә. *Офицер шунда немецчалап акырып җибәрде һәм, кызып, котырынып, кулларын бутап, баш очындагы ботакны күрсәтте.* А. Шамов. *Ул үзе утырмады, урындык алып, Куртка утырырга немецчалап тәкъдим итте.* А. Гыйләҗев.

НЕ'НЕЦ *и.* РСФСРның Ненец, Ямал-Ненец, Таймыр милли округларында яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе. | *с. мәгъ.* Ненец халкына мөнәсәбәтле. *Ненец теле. Ненец әдәбияты.*

НЕО- Кушма сүзләрдә „яңа" мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: **неологизм, неодарвинизм, неоколониализм.**

НЕОГЕН *и. археол.* Җир тарихындагы өченчел чорның икенче яртысы.

НЕОЛИТ *и. археол.* Яңа таш дәвере, таш дәвереннән күп соң булган эпоха.

НЕОЛОГИЗМ *и. лингв.* Телдә яңа барлыкка килгән сүз яки сүз тезмәсе. *Телдәге неологизмнар.*

НЕОН *и. хим.* Һава составына керә торган иссез һәм төссез газ (электр лампаларында, төрле сигнал, реклама һ. б. ш. ны яктырту приборларында кулланыла). [*Химик элементлар*] *рәте инерт газлар, ягъни металл үзлекләре дә, металлоид үзлекләре дә булмаган элементлар вәкиле неон белән тәмамлана.* Химия. || *с. мәгъ.* Шул газны кулланып ясалган. *Алдагы ей түбәләрендә неон лампалардан ясалган рекламалар --- күңелле ялтырыйлар иде.* А. Расих. *Төнге утлар, неон реклама язулары --- тротуардагы чиксез күп күлләвекләрдә чагыла.* Каз. утл.

НЕРВ *и. анат.* 1. Кеше һәм хайваннар организмында ярсытуны периферидән баш һәм арка миенә яки, киресенчә, баш һәм арка миеннән периферигә тапшыра торган махсус җепселләр. *Баш мие нервларына үзәккә омтылучы җепселләрдән оешкан ис тою, күрү һәм ишетү нервлары керәләр.* Анатомия. [*Фельдшер Мәдинәгә бармакның*] *кайбер нервларына зарар килгән булырга мөмкин* [*диде*]. Ш. Камал.

2. Шул җепселләр системасының кешенең гомуми эшчәнлегенә, үз-үзен тотышына тәэсир итә торган хәле. *Докторлар, нервларың да бик нык какшаган дип, укуны бер елга калдырып торырга киңәш бирәләр.* Һ. Такташ. — *Ашаган кешенең нервысы нык була аның.* Р. Ишморат.

Нерв бозу — кәефне бозу, ачу китерү. **Нерв кайнау** — бик нык ачу килү, ярсу. *Ничә көннәр йокламаудан Исрафиловның нервлары кайнап чыккан чаклары иде.* Г. Ибраһимов. **Нерв кузгалу** — ачу килү, тынычлык бетү. *Гыйззәтнең нервлары кузгалган.* Ш. Усманов. **Нерв уйнау** — *к.* нервлану. *Чынчыннан нервысы уйный башлаган Нургали түзмәде— шактый дорфа итеп Сөләймановның сүзен тагын бүлде.* Ә. Еники. **Нервка тию, нервысына тию** — *к.* нерв бозу. *Габдулланың уңае килгән саен оешма правлениесенең эшләрен тәнкыйть итеп чыгышлар ясавы Әхмәдиевнең нервларына тия, каным боза иде.* Ш. Камал. **Нервларны бастыру** — тынычлану. *Башка командирлар, еш-еш кереп, нервларны бастырып өчен дегет шикелле куе кайнар чәй эчте.* Ш. Усманов. **Нервыда уйнау** — кемнең дә булса ачуын китереп, озак вакыт ошамаган нәрсә эшләү, сөйләнү, кәефенә тию. [*Арслан:*] *Нервыда уйнамыйм мин. Аңлатып әйтәм, катушканың пластинкалары юкарган, чыдамаячаклар.* Г. Ахунов.

НЕ'РВЛАНУ *ф.* Нервлар киеренке хәлдә булу. *Нервланып, әледән-әле сәгатькә карангалап утырган Хисаметдин балаларның кайда эшләүләре, ничек укулары турында сорашып утырды.* Ш. Хөсәенов. *Ул, озын походларда да арымаган егет, бүген бу унбиш чакрымлык юлдан арып, талчыгып, нервланып, ачуланып кайтты.* А. Шамов.

НЕ'РВЛЫ *с.* 1. Тиз ярсып китүчән, тиз кызып китүчән. — *Мин нервлы кеше.* Ш. Камал. *Һәрвакыт сабыр табигатьле укытучы, каушап, нервлы, бәйләнчек хатыннарча кызып китте.* Г. Гобәй. || Эчке ярсуны, дулкынлануны белдергән, сиздергән, күрсәткән. — *Тукта инде, чынлап уйныйбыз! — диде дә бөтен фигураларын нервлы куллары белән тактадан себереп төшерде* [*Зариф*]. Г. Ибраһимов. *Егет профессор каршына ук утырган, --- әледән-әле нервлы хәрәкәтләр ясап, кашларын җыергалап куя иде.* А. Расих.

2. Борчулы, ыгы-зыгылы; дулкынланырга, борчылырга мәҗбүр итә торган (эш, тормыш һ. б. турында). *Авыл шау-шулы һәм нервлы тормыш белән яши башлады.* А. Шамов.

НЕ'РВЛЫЛЫК *и.* Нервлы булу хәле.

НЕ'РПА *и. зоол.* Тюленьнәр семьялыгына керә торган ишкәк аяклы имезүче хайван.

НЕСЕССЕР *и.* Тегү кирәк-яраклары, туалет әйберләре һ. б. сала торган шкатулка, футляр, савыт. [*Кызылармеец*] *туалет әйберләре тутырылган несессердан бритва белән сабын порошогын алып, пыяла савыт, щётка, маникюр коралларын читкә ыргыткан.* Ш. Усманов.

НЕ'ТТО *и. махс.* Товарның савыттан һәм төрелгән нәрсәсеннән башка гына булган саф авырлыгы.

НЕФРИТ I *и. махс.* Яшькелт яки сөт төсендәге ак минерал (колонналар, бизәкләр һ. б. ш. нәрсәләр ясаганда файдаланыла).

НЕФРИ'Т II *и. мед.* Бөерләр ялкынсыну авыруы. *Ангинаның хроник тонзиллитка күчүе, соңгысының буыннарда ревматизм, --- бөерләрдә нефрит тудыруы ихтимал.* Ш. Хөсәенов.

НЕФТЕБА'ЗА *и.* Нефтьтән алган ягулык һәм төрле майлар белән тәэмин итә торган база.

НЕФТЕПРОВОД *и.* Нефть яки аны эшкәртү нәтиҗәсендә барлыкка килгән продуктларны еракка җибәрү өчен салынган трубалар системасы. *Нефть илтүне җиңеләйтү өчен нефтепровод төзелә.*

НЕФТЕПРО'МЫСЕЛ *и. махс.* Нефть чыгару эше белән шөгыльләнә торган предприятие.

НЕФТЬ *и.* Җир астыннан табыла торган, үзенә хас исле, карасу төстәге май сыман сыекча (ягулык буларак та, төрле продуктлар эшләү өчен чимал буларак та файдаланыла). *Су өстендә зур балдак кебек түгәрәкләнеп, тимгел-тимгел булып нефть ага иде.* А. Әхмәт. || *с. мәгъ.* Нефть чыгаруга бәйләнешле. *Аннары Татарстан җирендә --- бер-бер артлы нефть фонтаннары ата.* Г. Ахунов.

НЕ'ФТЬЧЕ *и.* Нефть промышленносте эшчесе; нефть белгече. *Су тимер күпер өстенә күтәрелергә тора. Нефтьчеләр салып биргән иде бу күперне колхозга.* Х. Хәйруллин. | *с. мәгъ. Нефтьче егетләр вахтага эшкә баралар.* А. Әхмәт.

НЕЧКӘ *с.* **1.** Аркылы кисеме бик кечкенә булган; *киресе:* юан. *Кулындагы нечкә чыбык белән Казлар куган була урамда.* һ. Такташ. *Ана* [*Гайшәдән*] *вак кадаклар белән чүкеч, нечкә җеп таптырды.* Г. Ибраһимов.

2. Нәфис җептән тукылган; *киресе:* калын. [*Кызның*] *өстендәге күлмәге ак төтен шикелле үтә күренә торган нечкә һәм озын.* Ш. Камал. — *Без бүген бит Сәрбинең бирнәгә дип әзерләгән нечкә кендерләрен тукмакларга гына килдек.* Г. Камал.

3. Юан яки симез булмаган; нәфис (кеше, аның фигурасы һәм тәненең аерым әгъзалары турында). *Нечкә бармаклар. Нечкә аяклар. Нечкә гәүдә.* □ [*Миңнурыйның*] *биле нечкә, буе зифа, коңгырт чәч толымнары билен узган, очлары элеккечә бераз сүтелеп торалар.* Г. Әпсәләмов. *Көчле кул Илсөярнең нечкә беләгеннән эләктереп алды.* Г. Гобәй.

4. Киңлеге, иңе зур булмаган, тар. *Нечкә сызыклар.* □ *Осиповның нечкә иреннәрендә --- елмаю сүнде.* Ш. Усманов.

5. Югары (тавыш, аваз турында). [*Берәү*] *ягымлы нечкә тавышы белән җыр башлады.* К. Нәҗми. *Кәримә, үзенә һич хас булмаган рәвештә, нечкә тавышы белән кычкырып ук җибәрде.* Ә. Еники.

6. Катлаулы, бик зур осталыкны, бик вак детальләренә кадәр игътибар биреп эшләүне таләп итә торган. *Нечкә күзәтүчәнлек. Нечкә механизм.* □ *Үзе машинага утырып йөри, ди. Гыймайның үз балалары-ның андый нечкә эшкә сәләте юк, диләр.* М. Фәйзи. *Кая инде ул уң кулга шундый нәзәкәтле нечкә эшкә* [*скрипка уйнауга*] *тотынырга.* Г. Бәширов. || Җаваплылык таләп итә торган, җаваплы, четерекле. *Процент хисаплары кебек нечкәрәк эшләр булганда, конторщиклар очына чыга алмаенча, гажиз кала торганнар иде.* Ш. Мөхәммәдев.

7. Тирәнгә яшерелгән, яшерен, бик кыенлык белән генә күренә, сизелә торган. — *Иптәш Иделбаева, — дидем мин.— Беләсезме, сезнең җырыгызны ишеткәч, табигатьнең нечкә серләренә төшенә алмаган вәхши шикелле булдым мин.* М. Әмир.

8. Исе, тәме нәзакәтле булган, нәфис. *Аның борынына юкә, сирень чәчәкләренең нечкә хуш исе белән бергә ак әремнең ямьсез әче исе килеп бәрелә.* Г Әпсәләмов.

9. Нәзакәтле (тәрбия, үзеңне тоту, сөйләшү һ. б. ш. турында). *Йомшак урындыклар, көзгеләр, --- кызыл агач шкафлар нечкә бер зәвык белән тезелгәннәр.* Г. Ибраһимов.

10. Үтә оста, үтә тапкыр; үткен; сизелер-сизелмәс, ниндидер яшерен мәгънәсе булган. *Яшьрәк йөзле, һәрвакыт нечкә ирония белән сөйләшә торган, --- оста сүз талантына ия булган Кави Нәҗмине Казан яшьләренең күбесе күреп белә торгандыр.* Г. Нигъмәти. *Мостафаның башка иптәшләре дә Нәгыймнең соңгы сүзләрендә бик нечкә үртәү тоны сизделәр.* Ш. Камал.

11. Саклык белән, әдәп, игътибар белән эш итүне, мөгамәлә итүне таләп итә торган. — *Гаилә тормышы кебек үтә нечкә, үтә четерекле эшләргә тыгылырга синең ни хакың бар?* Г. Ахунов. *Йөрәк шул — нечкә әйбер, Акыл алмый акылдан.* М. Җәлил. *Балалар бит алар, үзегез беләсез, бик нечкә халык.* Г. Минский.

12. Сизгер, йомшак (кеше, аның характеры һ. б. турында). *Моннан соң Миңнурыйны ничек кенә булса да исенә төшергән бөтен нәрсә аның нечкә һәм хисчән күңелен сөендерәчәк иде.* Г. Әпсәләмов. *Аннары әнә сылулыкта, чибәрлектә теләсә нинди гүзәлләрең белән тиңләшерлек нечкә күңелле Карлыгач* [*бар*]. Г. Бәширов.

Нечкә тартык аваз *лингв.* — телнең урта өлешен аңкауга якынайта төшеп әйтелә торган тартык аваз, палаталь аваз.

◇ **Нечкә тамак**—нәзберек, талымчан кеше турында.

НЕЧКӘЛЕК *и.* **1.** Нечкә булу сыйфаты. *Мин сурәтли алмам зифалыгын, Нечкәлеген сезгә биленең.* М. Җәлил. [*Йорт*] *үзенең архитектура стиленең матурлыгы, нечкәлеге белән шәһәрдәге иң матур йортлар арасында беренче урынны тота.* Ш. Камал.

2. Бик кечкенә ваклыклар, детальләр. *Картның хикәясендә, гадәттәгечә, барлык нечкәлекләренә кадәр тукми-чәчми сөйләү һәм ярыйсы гына күпертү өлеше дә булмады түгел.* Г. Минский. [*Миңнур карт*], *булып үткән вакыйганы бөтен нечкәлекләренә кадәр уйлап, тикшереп чыкканнан соң, Шәрифулланың --- киләчәгенә ышанды.* А. Шамов.

Нечкәлек билгесе *лингв.* — 1) „ь“ хәрефенең атамасы; 2) транскрипциядә: тартык авазларның нечкә әйтелешен белдерү өчен, аларның уң ягына, өскә куела торган билге (').

НЕЧКӘЛӘНҮ *ф.* **1.** *к.* нечкәләү (1 мәгъ.). [*Барый*], *артык нечкәләнеп, әдәп-фәлән саклап тормыйча, --- Фәридәнең башына каплаган юрганын аскарак тартты.* Н. Фәттах.

2. *к.* нечкәрү **3.** *Мирычның шушылай көтмәгәндә нечкәләнеп фәлсәфәгә бирелүе сәер дә, кызык та тоелды Фуатка.* Ә. Касыймов.

НЕЧКӘЛӘҮ *ф.* **1.** Җентекләп уйлау, нәрсәнең дә булса һәр ягын, барлык ваклыкларын исәпкә алу, төптән уйлау. [*Таибә абыстай:*] *Һай, артык нечкәлисең, улым! Бераз күзне йомыбрак тәвәккәләү дә кайчак хәерлегә була ул.* Ә. Еники. [*Нәфисә үзенең*] *бик артык нечкәләп маташуына ачуы килеп, тиз-тиз конвертны ачты.* Г. Бәширов.

2. Берәр нәрсәне җиренә җиткерү, кагыйдәсенә китереп эшләү. — *Чокыр Хәбип йортында кияүнең атын җигә башлаганнар инде, --- бик нечкәләмәсеннәр, тизрәк булсыннар, дип әйтте* [*Фәтхия әби*]. Г. Ибраһимов.

3. *рәв. мәгъ.* **нечкәләп.** Нечкә итеп. [*Хуҗа хатын*] *мич башыннан нечкәләп-нечкәләп телгәләнгән коры каен чыраларын алды да лампа урынына яндырып җибәрде.* Г. Ибраһимов. || Төпченеп, җентекләп. *Хәят портретны бик озаклап, бик нечкәләп карады, иң вак нәрсәләрне дә күзеннән төшереп калдырмаска тырышты.* Ф. Әмирхан. [*Без*] *эшнең ничек алай килеп чыгуы турында нечкәләп сорашырга өлгерә алмый калдык.* М. Әмир.

НЕЧКӘРТҮ *ф.* 1. Тагы да нечкәрәк итү, нечкә хәлгә җиткерү. [*Зөһрәнең*] *юбкасы нечкә билен тагын да нечкәртеп күрсәтә.* Н. Фәттах.

2. *күч.* Тәэсирләндерү, хискә бирелдерү (күңел һ. б. турында). *Музыканың кешеләрне сихерли торган моңы --- Закирның күңеленә тула, тойгыларны тагын да үткенәйтә, нечкәртә.* И. Гази. *Бу сөйкемле кызчыкның сүзләре Мохтарның күңелен тагын нечкәртеп җибәрде.* Ш. Камал.

3. *лингв.* Йомшарту; палатальләштерү.

НЕЧКӘРҮ *ф.* 1. Нечкәгә әйләнү, тагы да нечкәрәк хәлгә килү. *Эч каеш белән тарттырган кебек нечкәреп, тип-тигез булып эчкә керде.* Г. Ибраһимов.

2. Гадәттәгедән нечкәгә әйләнү, югары тонга күчү (тавыш, аваз турында). *Чү, кайдандыр Газинурга бик яхшы таныш булган озын-озын зырылдау тавышы ишетелә. Зырылдау бер нечкәргәндәй була, бер тагын да калыная төшә.* Г. Әпсәләмов.—*Сестра!* — *диде* [*Хәлим*], *ләкин тавышының үзгәрүенә, аның кинәт нечкәреп, калтыранып чыгуына үзе дә гаҗәпләнеп туктап калды.* А. Шамов.

3. *күч.* Тәэсирләнү, хискә бирелү, шәфкатьләләнү (күңел һ. б. турында). *Өйдә, йортта шау-шу, көлеш, Җырга күңел нечкәрә.* М. Җәлил. *Озатучыларның күңелләре тагы да нечкәрә төште.* М. Гафури.

4. *лингв.* Йомшару; палатальләшү (аваз турында).

НИ I *а.* 1. *к.* нәрсә (1 мәгъ.). *Рәшит: Ни булды сиңа, Гөлзадә?* Р. Ишморат. || Гомумән берәр әйберне, нәрсәне дә булса **белдерә**. *Әмин нидән тотырга белмичә торам да торам.* Ф. Хөсни. *Күңел бушлыгын ни белән булса да тутырырга кирәк иде.* Г. Бәширов.

2. Риторик сорау һәм өндәү җөмләләрдә „нинди“ мәгънәсендә килеп, нәрсәнең дә булса бөтенләй булмавына ишарә итә. [*Бәдри:*] *Өч-дүрт кенә кеше ни кызык табып утыралар икән?* М. Фәйзи. *Әүлап карасаң, минем ни гаебем бар?* Ф. Хөсни.

3. Нәрсәгә дә булса кимсетүле мөнәсәбәтне белдерә. *Алма ашыйлар, алма ашыйлар, Алманың ни туклыгы.* Җыр.

4. Риторик сорауларда һәм өндәүләрдә „нинди“ мәгънәсендә килеп, канәгатьләнү, соклану һ. б. ш. ны аңлата. *Килгән кунаклар* [*Нәҗиянең*] *ашларын --- мактый-мактый ашасалар, ни бәхет!* Ә. Еники.

5. „Шул“ алмашлыгы белән мөнәсәбәткә кереп, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Оясында ни булса — очканында шул булыр.* Мәкаль. *Ни чәчсәң, шуны урырсың.* Мәкаль.

6. Исемнәргә ялганып, парлы сүзләр ясый һәм мәгънәгә җыймалык төсмере өсти. *Өстәле-ние белән. Урындыгы-ние. Альяпкычы-ние.* □ — *Әмин, ахмак баш, җилememне банкасы-ние белән гаражда онытып калдырганмын.* А. Шамов.

◇ **Ни арада** — нәрсәнең дә булса тиз булуын, берәр нәрсәнең билгеле бер хәлгә килүен сизми калганда әйтелә. *Ни арада, ничек шулкадәр тиз үсә бу яшьләр.* Г. Бәширов. **Ни бар, ни булган** — барлык, һәммә. *Үзенең ни бар кайгыларын, Совет, революция эшләрендәге уңышларын аның белән уртаклаша иде.* Г. Ибраһимов. **Ни гомердән бирле** — бик озак вакыт, күптәннән бирле. — *И ходаем, мин сезнең белән ни гомердән бирле такылдап торам, әнилəр белән күрешергә исемә дә килмәгән.* Г. Рәхим. **Ни күзем белән күрим, ни күрәм** *кер. сүз.* — көтелмәгән хәлдән гаҗәпләнеп, аптырап калуны белдерә. *Ни күзем белән күрим, --- минем әнкәй, кузгала да, әндәшә дә алмыйча, авыр сулап ята.* Ш. Әхмәдиев. **Ни чарадан бичара** — аптыраганнан гына, башка чара булмаганга, гаҗизлектән генә. [*Сыерчыклар*] *--- күкәй салыр вакыт җиткәнгә генә, ни чарадан бичара гына әмәлләштереп кергәннәр.* Г. Гобәй. **Ни җитте** — 1) шәп булмаган, теләсә нинди, начар. *Аш пешерергә ни җитте сарык ите генә ярамый, үрдәк я каз ите салырга кирәк.* М. Гали. *Үзең эш эзли башлагач, бик тә кыен икән. Ни җиттесенә күңел ятмый, үзең баш тартасың.* С. Сабиров; 2) теләсә нинди, юньсез, начар (кеше турында). *Әти янына килеп йөрүчеләр ни җитте кеше булмаганнар инде алайса.* Г. Гобәй. [*Мәдинә:*] *Ни җитте кешегә киявгә чыгып, башыма бәла аласым юк.* Ш. Камал.

НИ II *кис.* 1. „Никадәр“ мәгънәсендә килеп, мәгънәне тагы да көчәйтә төшә. *Ни тырышып ишүгә карамастан, көймә ярга якынаймады.* Г. Гобәй. *Һашимнарның кайтуына да ни гомер узды.* Г. Әпсәләмов.

2. *-мый, -мыйча* кушымчасына беткән хәл фигыльләр янәшәсендә килеп, эш һәм хәлнең булуына каршы килүне, ризалашмауны аңлата. [*Берсе Фазыл турында:*] *Кыз өйдә юк шул, менә нәрсәгә өзелә ул...* [*Икенчесе:*] *Өзелде ди, өзелми ни.* Ә. Фәйзи. [*Сажидә:*] *Шунда* [*фермада*] *эшлəгəч, кайгыртмыйча ни. --- Бар да кайгырта.* Ә. Еники. || Ирония төсмере өсти. *Нәгыйм аны мыскыллаган тон белән әйтте:* — *Белдем, белдем! Син аңлаткач, белмичә ни!* Ш. Камал. || Шарт фигыль белән килеп, ис китмәүне, нәрсә белән дә булса ансат кына ризалашуны һ. б. белдерә. [*Хәкимҗан:*] *дй, сабан туе түгел ич. Егылса ни.* А. Әхмәт.

3. *терк.* Тиңдәш кисәкләр арасында кабатланып килеп, нәрсәне дә булса инкяр итүне белдерә. *Бу төшләргә килеп җитә алмый Ни бер сәлам, ни хат, ни хәбәр.* Х. Туфан.

НИ'БАРЫ *рәв.* Саннар янында килеп, предметның саны шуннан артык булмауны, барлыгы шуның кадәр генә булуны аңлата. *Завод күләмендә планның үтәлеше нибары йөз дә ике процент.* Р. Ишморат. *Билет алганнан соң, минем кесәдә нибары кырык тиен генә акча калды.* Г. Ризван.

НИВЕЛИР *и. махс.* Нивелирлау эшендә кулланыла торган геодезик инструмент. *Икенче бүлмәдә геодезистларның рейкалары, өч аяклы нивелирлары күренә.* Г. Әпсәләмов.

НИВЕЛИРЛАУ *ф.* Җир өстендә нинди дә булса ноктаның (яки нокталарның) берәр билгеләнгән нокта белән яки диңгез өсте тигезлеге белән чагыштырмача биеклеген билгеләү.

НИВХ *и.* Амур елгасының түбән агымында һәм Сахалин утравында яшәүче халык атамасы һәм шул халыкның аерым бер кешесе.

НИГЕЗ *и.* 1. Корылачак, урнаштырылачак нәрсәнең терәге булып хезмәт иткән корылма, аскы өлеш, фундамент. [*Һәйкәлнең*] *нигезе — дүрт почмаклы*

гранит өеме. Ш. Маннур. *Васил бу тарафларга килгәндә, - - - зур пулатларга нигезләр генә салына башлаган иде...* С. Рафиков. | *с. мәгъ. Череп беткән нигез бүрәнәләреннән тынчу ис аңкый.* А. Шамов. || Йортның тышкы стенасы буена, җылыту өчен, гадәттә туфрактан салынган биек булмаган өем. *Гафиятулла бабай - - - кайсыдыр төшереп калдырган утын кисәген аяк астыннан күтәреп, өй нигезенә илтеп куйды.* Г. Әпсәләмов. *Нигез туфрагында тавыклар коена.* И. Гази.

2. Төп йорт, ата-баба йорты; туган-үскән, гомер иткән йорт. *Ничәмә еллар яшәгән нигезеннән бер генә дә кубып китәсе килми* [*Тәзкирә апаның*]. Б. Камалов. *Йорт бит ул — гомерлек нәрсә. Китсәгез тагын кайтырсыз. Монда ичмасам нигезегез сакланыр.* Ә. Еники.

3. *күч.* Нәрсәнең дә булса барлыкка килүе өчен материаль база, мая. [*Алпавыт*] *җиренең байтагын тирә-як авылларга бирделәр, калганыннан, аның йортларын нигез итеп, „Уртак“ исемендә коммуна төзеделәр.* Г. Ибраһимов. || Нәрсәнең дә булса төп асылын тәшкил итә торган, нәрсәне дә булса барлыкка китерү өчен төп материал булып торган нәрсә, чыганак. *„Алтынчәч“ либреттосының нигезенә татар халык эпосы „Җик-Мәргән“ алынды.* М. Җәлил. *Бу гыйльми хезмәтнең нигезенә сезнең дә бөек һәм данлы укытучылык хезмәтегез салынган.* Г. Минский. || Берәр нәрсәнең төп факторы, җирлеге, таянычы. *СССРның политик нигезен хезмәт ияләренең депутатлар Советы тәшкил итә.* СССР Конституциясе. *Социализм системасы капитализм нигезен һәм аның нигез баганасы булган хосусый милек өстенлеген җимерде.* М. Җәлил. || Башлангыч, җирлек. *Хезмәт өештыруны фәнни нигезгә кору.* □ *— Авылны социалистик нигезгә күчерү өчен хәзерге аерым-аерым вак хуҗалыкларны берләштереп, әре хуҗалыкка әйләндерү кирәк.* М. Әмир.

4. Нинди дә булса фәннең башлангычы, төп положение. *Дарвинизм нигезләре.* □ *Газетада, татар большевигы Хөсәен Ямашев һәм революционер язучы Гафур Коләхметовлар ярдәме белән, марксизмның нигезләре - - - турында озын-озын мәкаләләр басыла.* М. Гали. *Владимир Ильич бүген дә дәртләнеп, илһамланып Маркс теориясенең нигезләре турында сөйли башлады.* Г. Әпсәләмов.

5. Нәрсәнең дә булса асылы. *Без кул күтәрәбез Хаклык нигезе булган һәр кешегә эшләп Яшәү шарты өчен!* М. Җәлил. *Эш — тормышның нигезе.* Р. Ишморат. || *с. мәгъ. Шакир нигез директивалар сөйләде.* Г. Ибраһимов. *Шушы тәртип һәм шушы нигез сызыкларны* [*Әхмәт*], *әлбәттә, үзенең биш бармагын белгән төсле, күңеленнән дә белә.* Ш. Камал.

6. Кешенең үз-үзен тотышын, тәртибен һ. б. аңлата, аклый торган сәбәп, дәлил, аргумент. *Ольганы яраткан литейщикларның борчылырга нигезләре дә бар иде.* Г. Әпсәләмов. *— Ни өчен син шулай дип уйлыйсың? Нинди нигезең бар?* И. Гази.

7. Мөмкинлек; хокук, хак. [*Милли татар частена*] *әләгергә формаль нигезләрем булмаганга гына шулай бит ул.* М. Җәлил.

8. *тех.* Тукымадагы буй җепләр. | *с. мәгъ. Станок төрләп эшли башлагач та, - - -* [*Садыйк*] *нигез җепләренә карап байтак вакыт айный алмый газапланды.* А. Расих.

9. *мат.* Геометрик фигураның биеклегенә перпендикуляр як, кыр. *Биеклек төшерелгән ягын өчпочмакның нигезе итеп алалар.* Геометрия.

10. *хим.* Тозның кислоталар белән үзара тәэсир итешүе аркасында хасил булган кушылма. *Нигезләрнең күпчелеге суда эреми.* Химия.

11. *лингв.* Сүзнең төп лексик мәгънәне белдергән һәм тамырдан башка ясагыч кушымчаны да үз эченә алган өлеше. [*Сүзләрдә*] *нигез ике төргә аерыла: тамыр нигез, ясалма нигез.* В. Хангилдин.

Нигез кору (булдыру) — үз йортыңны булдыру, йорт салу. [*Гыйлажи Солтанга:*] *Ну, егет, сиңа яңа нигез корабызмыни?* Г. Ибраһимов. **Нигезе кору** — юкка чыгу, бетү, үлү. **Нигезен корыту** — берәр нәрсәне бөтенләй юкка чыгару, бетерү; тамырын корыту. *— Шәйхулла комсызның нигезен корытмакчы идеңме син?* Д. Аппакова. **Нигез күрше** — янәшә күрше. *Мәһи белән Мәликә, ике карчык, нигез күршеләр, тату гына гомер кичерәләр иде.* Ф. Хөсни. **Нигез салу** — 1) *к.* нигез кору; 2) берәр нәрсәне, эшне башлап җибәрү. *„Чулпан“ колхозының яшь пионерлары, киләчәктә безнең тормышыбыз тагын да ямьлерәк булсын өчен, менә шушы зур бакчага нигез салалар.* Г. Бәширов. **Нигез ташы** — берәр нәрсәнең башлангычы. *Татар театрының беренче нигез ташын салып, аны үстерүчеләрнең берсе — Г. Камал.* М. Гали. **Нигез ясау** — берәр нәрсәгә җирлек әзерләү, берәр нәрсә әзерләп кую. *— Алайса мин* [*Казанга*] *барып урнашыйм һәм сиңа да нигез ясап куйыйм.* Ә. Фәйзи.

НИГЕЗДӘ *кер. сүз.* Гомумән алганда, асылда, төбендә. *Дәвер, нигездә, әкият төсендә төзелде.* М. Җәлил. *Бер редактор минем китапны карап чыккач, „әйбәт“ дип тапты. — Нигездә, — ди, — яхшы әшләнгән.* Б. Рәхмәт.

НИГЕЗДӘН *рәв.* Бөтенләйгә, тулысынча. *Эшне нигездән үзгәртәчәкмен.* З. Мансур. [*Яруллина тәкъдиме*] *— сыйфат өчен, бракны нигездән бетерү өчен конкрет көрәш.* Р. Ишморат.

НИГЕЗДӘШ *с.* Нигезләре янәшә, күрше булган яки уртак нигездә салынган йортта торучы. *Гөлгенәләр Хәлимнәргә нигездәш күрше.* Г. Гобәй.

НИГЕЗЕНДӘ *бәйл.* Берәр нәрсәгә нигезләнеп, таянып. *— Без геолог Рәхимә Сәлимова белән, соңгы тикшерүләр нигезендә, Бизмән тауда нефть булырга тиеш, дибез.* А. Әхмәт.

НИГЕЗЛЕ *с.* 1. Нигезе (1 мәгъ.) булган. [*Хәсән*] *таш кыядай биек нигезле часовняны узып дамбага борылганчы артына карап барды.* К. Нәҗми. || Йорты-җире булган. *Ике сүлпән табигатьле кешенең гаилә төзеп, нигезле рәвештә көн күрү бусагасына аяк басуы үзе генә дә гомумән тормыш яхшыра барганлыкны - - - күрсәтә түгелме?* Ш. Камал.

2. Төпле, тирән эчтәлекле (белем, фикер һ. б. ш. турында). *Ап-ачык тор һәрвакытта, И китап, багам сиңа, Чын, асыл нигезле җирдән Күп белемнәр бир миңа!* Ш. Бабич.

3. Җитәрлек дәлилләре, сәбәпләре булган; нигезләнгән, ышандырырлык. *Үтенече нигезле.* □ *дәе, прокурор Саттаров безнең шикләрнең нигезле булуына шикләнә иде.* Каз. утл.

4. Чынбарлыкка туры килә торган, дөрес. *Гайнелвафа карчык сөйләгән имеш-мимеш нигезле булып чыкты.* М. Мәһдиев.

5. Урынлы. *Авылдагы һәр ишекне тупсасына хәтле каерып ачып керергә хакым бар дип уйлый иде* [*Шәрифуллә*], *һәм - - - ул бик нигезле хак иде. Ул — мичче.* А. Шамов.

НИГЕЗЛЕЛЕК *и.* Нигезле булу. *Дәлилләрнең нигезлелеге.*

НИГЕЗЛӘНҮ *ф.* 1. Ышандырырлык, җитди дәлилләр белән исбатлану, дәлилләнү.

2. Йорт салып килеп утыру, шул урында төпләнеп калу.

3. Берәр нәрсәгә таянып эш итү, шуннан файдалану. [*„Яшь йөрәкләр“*] *баштанаяк романтикликка нигезләнеп язылган.* Г. Нигъмәти.

НИГЕЗЛӘҮ *ф.* 1. Нигез салу, башлап җибәрү. *Тукай татар әдәбиятындагы критик реализмның көчле сатирик мәктәбен нигезләде.* Г. Халит.

2. Ышандырырлык, җитди дәлилләр белән исбатлау, дәлилләү. *Гыйльмановның сүзне Фәтхи һәм Сәмигуллин уйламаган якка борып, аны шактый оста нигезләве аркасында, бу соңгыларда беркадәр тынычлану туды.* Ш. Камал. *Хәнәфи гражданкага күчүнең Ләмига уйлаганча ук ансат эш түгеллеген аңлатып карады, фикерен үзенчә нигезләде дә.* Б. Камалов.

3. Берәр нәрсәгә таянып эш итү, шуннан файдалану, берәр нәрсәне чыганак итү. *Г. Камал татар әдәби проза телен чын халык теленә нигезли.* М. Гали.

НИГЕЗСЕЗ *с.* Нигезе булмаган, урынсыз, дәлилсез, бер нәрсә белән дә исбатланмаган, расланмаган. *Шакир турындагы һәртөрле шикле-микле уйларның нигезсез булуын --- яхшы белә иде дминә.* Г. Минский. *Иптәшләр, комиссия чыгарган нәтиҗәләрне нигезсез һәм тенденциоз санап, бюро утырышына куюдан баш тарттылар.* С. Рафиков.

НИГЕЗСЕЗЛЕК *и.* Нигезсез булу, нигезләнмәгән булу, дәлилсезлек.

НИГИЛИЗМ *и.* 1. XIX йөзнең 60 нчы елларында рус иҗтимагый фикере тарихында дворян җәмгыяте нигезләрен, аның культурасын, традицияләрен, крепостнойлыкны кире каккан юнәлеш.

2. *күч.* Барлык нәрсәне инкяр итү, һәркем тарафыннан кабул ителгән нормаларны танымау. [*Сарымсаков Гөлнурга:*] *Тәнкыйть итәм дип, милли нигилизмга бирелмәгез.* Г. Ахунов.

НИГИЛИСТ *и.* 1. Нигилизм тарафдары.

2. *күч.* Барлык нәрсәне инкяр итүче, һәркем тарафыннан кабул ителгән нормаларны кире кагучы кеше.

НИГИЛИ'СТИК *с.* Нигилизмга хас булган. *Нигилистик карашлар.*

НИГЪМӘТ *и. иск.* Ашамлык, ризык. *Хәтирә апа төрле-төрле тәмле нигъмәтләр белән тулы өстәлне кабат рәтләгән --- арада сөйләнгәләп тә алды.* М. Хәсәнов.

НИ'ГӘ *а.* 1. Нинди максат белән. — *Сиңа нигә ул?* Т. Гыйззәт. || Ни сәбәпле, ни өчен, ник. [*Фәридә Хәйдәргә:*] *Нигә бакчага чыгып утырмыйсыз?* Р. Ишморат. *Сабира апа, нигә моңайдың?* М. Җәлил.

2. Сорау кисәкчәсе мәгънәсендә килеп, сорау җөмләнең башында сорауны көчәйтү өчен кулланыла. [*Рәхимә:*] *Нигә, икесе дә табылса начар булырмыни?* А. Әхмәт.

Нигә шунда — иярчен кире җөмләне баш җөмләгә теркәү өчен кулланыла. *Нигә шунда кояш януыннан туктамый яисә күк җиргә ишелеп төшми, алар шунда да керфек тә какмаячаклар.* И. Гази.

НИ'ГӘДЕР *а.* Ниндидер билгесез сәбәп (яки максат) белән. *Гафиятулла абзый бигрәк тә Газинурга каты ачулана, Мисбахка нигәдер тел тидерми.* Г. Әпсәләмов. *Нәфисәнең сүзләре шаян булса да, йөзе нигәдер борчулы күренә иде.* Г. Бәширов.

НИДА *и. иск.* 1. Өндәү, чакыру авазы, тавыш. *Яңгырата хәзер җирнең йөзен Әшчеләрнең көчле нидасы.* М. Гафури. *Агач, таш эчләре шаңрап, Килә дер бер нида яңрап!* Дәрдмәнд.

2. Зар-ыңгырашу тавышы. *Кара тупрак тулы мазлум нидасы.* Дәрдмәнд.

НИДАЛЫ *с. иск.* Күтәренке, шат (тавыш турында). *А, безнең иске дуслар! Сагындырдыгыз! Хуш киләсез! — шундый нидалы тавышлар белән кунакларны түргә әйдәде* [*Мария*]. Ш. Маннур.

НИ'ДЕР *а.* Билгесез бер нәрсә, күренеш, предмет. *Стена артында --- нидер авып төште, кемдер әрнеп кычкырып җибәрде.* Ә. Фәйзи. *Хәсән кичә сөйләшкән яшь матроска нидер әйтмәкче иде, туктап калды.* К. Нәҗми.

НИДЕРЛАНД *и.* Голландиянең төп халкы; голландлылар.

НИ'ДӘН *а.* Ни сәбәпле, ни сәбәптән, нинди сәбәп аркасында, нинди вакыйга уңае белән. *Мусага уңайсыз, эче поша, нидән икәнлеген дә белми.* Ш. Камал. [*Шагыйрь — кызга:*] *Әйтче: нидән шулай яшь егетләр Гөл сибәләр синең алдыңа?* Н. Исәнбәт.

НИ'ДӘНДЕР *а.* Нинди дә булса сәбәптән, билгесез сәбәптән. *Нидәндер йөрәгем жу-у итеп китте.* Г. Ибраһимов.

НИЗАГ *и. иск.* Ызгыш, талаш, гауга. *Зыя Кәримнән берничә дәрәҗә алда булып, аның һәммә сабакларын өйрәтә, төрле низагларда үз итә, яклаша иде.* Г. Ибраһимов. *Бертуган кебек тату яшәп килгән кешеләребез арасында низаглар чыга башлады.* М. Әмир.

НИЗАГЛАШУ *ф. иск.* Талашу, ызгышу. [*Буладыр шундый кеше*], *Һөнәр күрер кеше белән талашуны, Юк җирдә низаглашып ала ачуны.* М. Гафури.

НИЗАГЛЫ *с. иск.* Бәхәсле, гаугалы, талашлы. *Съездда: --- сугышка караш, җир-су мәсьәләсе, эшчеләр мәсьәләсе кебек, шул көннәрнең иң низаглы, талашлы мәсьәләләре куелган иде.* М. Гафури.

НИЗАГЛЫЛЫК *и. иск.* Низаглы булу, гаугалы, бәхәсле булу.

НИЗАМ *и. иск. к.* тәртип (1—3 мәгъ.). [*Астрахань*] *шәһәре низамсыз, --- биналары начардыр.* Ф. Әмирхан. *Иске низам котырып җан бирә нәгърә орып, Шашадыр торып-торып каргалганын белдея.* М. Гали.

НИЗАМЛЫ *с. иск. к.* тәртипле. *Садыйк тарафыннан низамлы мәдрәсә мөдирләренең хәрәкәтләре тагы да катырак тәнкыйть ителергә вә көленергә тиеш иде.* Ф. Әмирхан.

НИЗАМНАМӘ *и. иск.* Берәр төрле мәсьәләгә карата язылган закон, кагыйдәләр җыелмасы, устав. *Низамнамә, үзенең рамнары, пыялалары белән түбәнгә, таш идәнгә төшеп, чалдыр-чолдыр ватылып та өлгерде.* Г. Ибраһимов. *Сугыштан соң ике дәүләт арасында төзелгән сәүдә трактаты һәм кергән-чыккан товарлардан чик салымы* [*таможня*] *алу турында низамнамәләр төрки теленә күчерелеп, 1783—1784 елларда Петербургта басылганнар.* И. Рәмиев.

НИК *а.* 1. Ни өчен, нинди максат белән. *Ишектән чыгып китәр алдыннан Нуруллин командирдан ник чакырганын сорады.* А. Шамов. [*Хәлил:*] *Ник килдем мин монда?* М. Фәйзи.

2. Тойгылы җөмләләрдә өченче зат боерык фигыльләр белән килеп, эш яки хәлнең бөтенләй үтәлмәвен, булмавын белдерә. *Ник бер генә җирдә бер генә ут булсын!* Г. Әпсәләмов. [*Хәсән*] *ник бер үзгәрсен, --- нәкъ әүвәлгечә, ябык, нечкә.* Ә. Еники.

НИ'КАДӘР *а.* 1. Предметларның саны, микъдары турындагы сорауны белдерә; күпме. *Я инде, итекче үзенең итеге өчен никадәр киндер алырга тиеш?* Г. Тукай. *Җәүдәт Мансуров ак сакаллы бабасын никадәр генә эзләсә дә таба алмады.* Г. Бәширов.

2. Гадәттә тойгылы җөмләләр составында килеп, берәр нәрсәнең бик күп санда яисә микъдарда булуын белдерә. *Ах әни, бу көннәрдә минем никадәр йөрәгем кайнаганын белсәң иде.* Ф. Әмирхан. || *Әллә, менә, әнә* кебек сүзләр янында шул ук мәгънәне белдерә, ләкин мәгънәсе тагын да көчәя төшә. *Ул әллә никадәр хатын-кыз, бала-чага кайнаша, урталык ду килә!* Ш. Камал.

3. Иярченле кушма җөмлә кисәкләрен бәйләүче мөнәсәбәтле сүз функциясендә кулланыла. *Кешенең никадәр әйбәт дуслары, танышлары булса, шулкадәр ул бәхетле.* Г. Минский. *Баланы никадәр иркәләсәң, шулкадәр бозыла гына.* Т. Гыйззәт.

НИ'КАДӘРЛЕ *а. к.* никадәр. *Никадәрле күп бүләк!* М. Җәлил. *Сәлим үзенең никадәрле мактаулы эш эшләгәнен хәзер генә аңлый башлады.* Г. Гобәй.

НИКАХ *и.* 1. *иск.* Өйләнешүне, гаилә төзүне шәригатьчә, махсус дога укытып, беркетү йоласы. [*Мавия:*] *Әйе, минем дә Бәкер абзый белән тиздән никахым була.* М. Фәйзи. *Бөтен никахны* [*икенче бүлмәдәге хатын-кызлар да*] *ишетеп тордылар.* Г. Ибраһимов. || Кемнең дә булса хатыны (ире), тормыш иптәше булу хәле. *Мәрьям белән аларның никахларына алты гына ел иде.* Ш. Камал.

2. Ир белән хатынның рәсмиләштерелгән гаилә союзы. — *Тик шунысы ачык — безнең никахны уңышлы итеп санап булмый, — дип исәп йөртте* [*Васил*]. С. Рафиков. *Тик паспортта гына никах билгесе калды.* М. Мәһдиев.

Никах мәҗлесе *иск.* — никах укыганнан соң була торган ашау-эчү мәҗлесе. *Никах мәҗлесенә килергә тиешле илле кеше алдан ук чакырылган.* Г. Ибраһимов. **Никах уку (укыту)** *иск.* — никах йоласын башкарганда махсус дога укып, никахны шәригатьчә раслау. — *Мулла никах укыды, Вәсилә хәзер минеке инде.* Ф. Хөсни. **Никах яңарту** *иск.* — 1) шәригать буенча никахта торуның нинди дә булса бер шарты бозылганда, никахны яңадан кабатлау; 2) башка хатынга өйләнү.

НИКАХЛАНУ *ф.* Өйләнү. [*Ризван:*] *Мәхдүмнәрнең берсенә никахланып алсаң, --- дәүләт байлыгы да, шөһрәт абруе да табыла.* Т. Гыйззәт.

НИКАХЛАНЫШУ *ф.* Кем белән дә булса никахка (1 мәгъ.) керү, өйләнешү.

НИКАХЛАП *рәв. иск.* Никах белән, никах нигезендә. [*Мөгълифә әнвәр турында:*] *Никахлап алган өч хатыны бар, хатыннары берсе-берсеннән чибәр.* Г. Камал.

НИКАХЛЫ *с.* 1. *иск.* Никахы (1 мәгъ.) булган, никах (1 мәгъ.) укытып иргә барган (өйләнгән). [*Рәүфә:*] *Мин бит аларга ялчы булып түгел, Сафаның никахлы хатыны булып бардым.* А. Шамов. [*Искәндәр Лаләгә:*] *Кит аның яныннан! Син хәзер никахлы кыз.* М. Фәйзи.

2. Законлы, закон белән рәсмиләштерелгән (ир, хатын).

НИКАХСЫЗ *с. иск.* Никах укылмаган, никахы булмаган; законсыз, вакытлы гына бергә тора торган. [*Камали:*] *Мин улымның никахсыз хатын белән торуына ризалык бирәсем юк.* Ф. Бурнаш. *Без икәү: динсез, никахсыз — бер өйдә.* Һ. Такташ.

НИ'КЕЛЬ *и.* Көмеш сыман ак төстәге, бик ялтыравыклы, авыр эри торган металл.

Никель йөгертү — *к.* никельләү.

НИ'КЕЛЬЛЕ *с.* Никельләнгән, никель белән капланган. *Никельле кровать, --- зур көзге, фикус, роза гөлләре, савыт-саба шкафы --- белән бизәлгән „кунак як" бай сыман матур гына иде.* А. Расих.

НИ'КЕЛЬЛӘҮ *ф.* Никель йөгертү, никель белән каплау.

НИ'КЕЛЬЛӘҮЧЕ *и.* Никельләү белән шөгыльләнүче эшче, никельләү остасы.

НИКОТИН *и.* Тәмәкедә була торган наркотик матдә. *Организмга никотин тәмәке тартканда керә.* Анатомия. *Чәй тирәсендә тешләре никотин белән лаклангән түбәтәйле Үзбәков Ахун, тагын бер карт кына кеше һәм бер тәбәнәк студент утыра иде.* А. Таһиров.

НИКРУТ *и. иск. сөйл. к.* рекрут. *Төштән соң каралу башланачак булганга күрә, аз саннылы номерлар чыккан никрутлар, ашарга да кайтмый, шунда көтеп үткәрделәр.* М. Гафури.

НИКРУТЛЫК *и. иск. сөйл. к.* рекрутлык. [*Егет*], *каралырга язылганнан бирле, үзенең никрутлыгы белән мактанып, „курыкмыйбыз без, китәбез", дип йөри, диләр иде.* Г. Ибраһимов.

НИ'КТЕР *рәв.* Билгесез сәбәп аркасында, билгесез сәбәп белән. *Син һаман юк, никтер килмисең.* С. Хәким. *Шофёр „иптәш директор" дип дәшмәкче иде дә, никтер теле әйләнмәде.* Г. Әпсәләмов.

НИ'ЛЕКТӘН *а.* Ни өчен, ни сәбәптән, ни сәбәпле. *Без әйтәбез: „Нәфисә бригадасы йөз илле шешәр йөз процент бирәме? Бирә! Ә сез нилектән бирмисез?"* Г. Бәширов. | *рәв. мәгъ.* *Менә дустыгыз Мансурга карагыз сез, чәчләре нилектән агарганын сорагыз...* Р. Ишморат.

НИ'МФА *и. миф.* Хатын-кыз рәвешендәге алла, алиһә (табигатьнең төрле көчләрен гәүдәләндерә).

НИ'НДИ *а.* 1. Кемнең яки нәрсәнең дә булса үзенчәлеге, сыйфаты турында сораганда кулланыла. — *Нинди вакыйга турында әйтмәкче буласыз, Ольга Николаевна?* Ш. Камал. — *Нинди эш турында сорыйсың, Нургали? — диде Сәҗидә апа тыныч кына.* Э. Еники.

2. Риторик сорау һәм өндәүләрдә нәрсәне дә булса тулысынча инкяр итүне аңлата. *Нинди апа булсын ул сиңа! Нинди хуҗа ул бу йортка? Нинди сүз булсын!* || Кире җөмлә составында килеп, *теләсә кем, һәркем, кем дә* дигән мәгънәләрне аңлата. *Күзләрендә яшьлек, ямь, матурлык, Нинди йөрәк күреп сөенмәс!* М. Җәлил.

3. Риторик җөмләләрдә күренешләргә эмоциональ бәя бирүне яки шул сыйфатның, үзенчәлекнең иң югары дәрәҗәсен белдерә. [*Сәгыйть:*] *Чыннан да, нинди җыелыш инде ул хәзер!* Н. Фәттах. *Арыш басуы нинди матур дулкынлана!* И. Гази. | *Генә, әле* кисәкчәсе белән. *Бу симфониядә нинди генә авазлар юк!* Г. Кутуй. *Ә җырлары тагын әле нинди!* Р. Ишморат.

4. Гадәттә *менә, әнә* сүзләре янында: 1) алда сөйләнгән сыйфат һәм үзенчәлекне атамыйча, гомумиләштереп, аңа ишарә буларак кулланыла. *Әнә нинди көч яшеренеп ята икән анда!* Г. Бәширов; 2) берәр нәрсәнең сыйфаты, үзенчәлеге турында гомумиләштереп әйтүне белдерә. [*Мортаза:*] *Дәүләтбаев партия тарафыннан куелган җаваплы кеше булгач, мин аңа ышанып килдем. Ә ул әнә нинди икән.* Р. Ишморат.

5. Мөнәсәбәтле сүз функциясендә килә. *Өең нинди, көең шундый.* Мәкаль. *Дустың нинди, кадерең шундый.* Мәкаль.

6. Кемнең дә булса сүзләренә каршы килгәндә, инкяр мәгънәсендә кулланыла. — *Хатын кеше идеме әллә? — диде Хәлим.* [*Захаров:*] *Нинди хатын булсын!* А. Шамов. [*Искәндәрев Хәбибуллинга:*] — *Сезне вакытсыз борчырга туры килде. — Нинди борчу ди ул!* Э. Еники.

Нинди булса да — теләсә нинди. *Китап нинди булса да ярый.* **Нинди генә булмасын** — теләсә нинди булса да. *Нинди генә булмасын, ул сиңа барыбер ана.* Каз. утл. **Нинди дә булса** — берәр төрле, берәр нинди. *Алай булгач,* [*трактор ның*] *кешесе нинди дә булса бер бәхетсезлеккә очрап төшеп калган.* М. Әмир. **Нинди җилләр ташлады** — кемне дә булса озак вакыт күрми торганнан соң очрашкач әйтелә. [*Рәхим Мансурга:*] *Нинди җилләр ташлады сине безгә?* Р. Ишморат.

НИ'НДИДЕР *а.* Берәр нәрсәнең сыйфатын, үзлеген ачык билгели алмаганда, билгесез булганда кулланыла. *Ерак тау артында ниндидер яктылык. Шуннан таң калка.* Ф. Кәрим. *Баш очында гына ниндидер кош чөкерди.* И. Гази.

НИ'ППЕЛЬ *и. махс.* Трубаны, шлангларны һ. б. герметик тоташтыра торган көпшә формасындагы деталь.

НИРГӘ *и.* **1.** Бүрәнәдән салынган корылмаларда озынчык формасын тәшкил иткән һәрбер горизонталь рәт. *20 ниргәле йорт.* □ *Мәктәпнең дә, клубның да ниргә араларын тышкы яктан сылап чыгу өчен ак балчык кирәк.* Г. Галиев. *Санап чыгар иде ниргәсен ул, Бурап бетергәч үк бурасын.* Б. Рәхмәт.

2. Нигез, фундамент. *Тиздән туар матур зур каланың Шушы, ахры, тәүге ниргәсе.* Ш. Маннур.

НИСАН *и. иск.* Апрель ае яңгыры, ләйсән. *Яз булды, нисан ява пыскып, карлап.* Дәрдмәнд.

НИСБИ *с.* Нәрсәгә дә булса бәйләнешен, мөнәсәбәтен күрсәтә торган. *Нисби сыйфатлар.*

НИСБИЛЕК *и.* Нисби булу. *Төшенчәнең нисбилеге.*

Нисбилек теориясе — хәзерге заман физика фәнендә: пространство һәм вакыт турындагы теория.

НИСБӘТ *и.* Кемнәр яки нәрсәләр арасындагы бәйләнеш, мөнәсәбәт. *Кадими бер хәлфә исә һәрвакыт: „Егетләр, менә Зыя белән музыка арасында нинди нисбәт? Нинди галәмә? — дип көлә иде.* Г. Ибраһимов. || Үзара бәйләнеш, төрле нәрсәләрнең, күренешләрнең бер-берсенә мөнәсәбәте. *Алар белән ике арада булган нисбәт Безләргә караганда тәмам башка.* М. Гафури.

НИСБӘТЕНДӘ *бәйл.* Исемнән соң килеп, „мөнәсәбәтендә", „аркасында", „шартларында", „карата" дигән мәгънәне аңлата. *Шәхси тормышының юклыгы нисбәтендә Тукаев үзенең әдәби тормышына ныграк бирелә.* Ф. Әмирхан.

НИСБӘТЛЕК: нисбәтлек теориясе — *к.* нисбилек теориясе.

НИСБӘТӘН *рәв. иск.* Кемгә яки нәрсәгә дә булса бәйләнешле рәвештә, берәр нәрсә белән чагыштырганда. *Дсәр, искеләргә караганда бик яңа күренсә дә, яңаларга нисбәтән иске күренәдер.* Ф. Әмирхан. *Йортларын сатучылар күп булды, һәм, азык бәяләренә нисбәтән, арзан гына алырга да мөмкин иде.* Ә. Еники.

НИТКӘН *а. сөйл. к.* нинди (1, 2 мәгъ.). *Бу ниткән буталыш, кем монда җыелырга кушты?* К. Нәҗми. [*Ишнияз:*] *Ниткән эшең бу, Хәнифә килен, фалнамә ачып утырасың түгелме соң?* Р. Ишморат.

НИТРАТ *и. хим.* Азот кислотасы тозы. *Нитрат бактерияләре.*

НИТРОГЛИЦЕРИН *и. хим.* Азот һәм күкерт кислотасы белән глицерин кушылмасыннан торган май сыманрак сыек матдә (шартлаткыч матдә буларак һәм медицинада дару буларак кулланыла). *Врач килгәнчегә кадәр [йөрәге авырткан] кешегә тулы тынычлык тәэмин итәргә һәм валидол яки нитроглицерин бирергә кирәк.* Йорт эшләре.

НИТРОН *и.* Йонны алмаштыра торган ясалма җепсел.

НИТРОЭМАЛЬ *и.* Автомашиналар буяу өчен кулланыла торган махсус буяу.

НИТҮ *ф.* **1.** Нинди дә булса эш башкаруны белдерә. [*Солдатлар:*] *Андый-мондый булсам, --- нитәрсең инде, туган, өйдәгеләргә язарсың, — дип, берберсенә өй адресларын бирештеләр.* Г. Бәширов. *Яле, Гайниҗамал, әнә шушы төенчектә азрак әлеге ни бардыр, азрак нитеп алыйк.* Ш. Камал.

2. Парлы сүзләр составында килеп, мәгънәгә гомумиләштерү, абстрактлаштыру төсмерен өсти. *Мин аларны уйлап-нитеп тормадым, башыма килгән нәрсәне әйттем дә җибәрдем.* Ф. Әмирхан. [*Рабига:*] *Шәһәрдән китсәм-нитсәм,* [*картинаны*] *үзләрендә калдырып тормакчы булам.* А. Шамов.

НИФАК *и. иск. кит.* Тыштан яхшы булып күренгән эшәкелек; икейөзлелек, монафыйклык, күз буяучылык, алдакчылык. *Бетәр шунда бу көндәге хөсет, нифак вә дошманлык.* М. Гафури. *Бетсен, кадалсын нифак.* Г. Тукай.

НИФАКЛЫ *с. иск. кит.* Икейөзле, монафыйк. *Бу елмаеш вә бу елтырану Шакирга шулкадәр самимиятсез, нифаклы шикелле тоелды.* Ф. Әмирхан.

НИ'ХӘЛ Хәл-әхвәл һәм исәнлекне белергә теләп сораганда кулланыла.— *Нихәл, Имәли абзый, көннәр ничек үтә?* М. Әмир.

Нихәл итү — аптырашта калуны, нишләргә белмәүне аңлата. *„Нихәл итим, нәрсә дип әйтим", — дип, яшьле күзләрен яшерер өчен читкә борылды* [*Хәдичә түти*]. Г. Бәширов.

НИ'ЧАКЛЫ *а. к.* никадәр. *Усемлеккә кояш нурлары ничаклы кирәк булса, балага ана мәхәббәте, ана иркәләве шулчаклы үк кирәк.* Г. Гобәй. *Егет, ничаклы гына үзен кайгы-сагыш баскан булса да, көлмичә түзә алмый.* Г. Минский.

НИЧЕК *а.* **1.** Эш яки хәлнең ни рәвешле булуын сораганда кулланыла. *Туктa, кайдан килдең син монда? Ничек кердең минем янына?* Ф. Бурнаш. || *рәв. мәгъ.* „Ни рәвешле", „нинди итеп" дигән мәгънәләрне аңлата.

2. Риторик сорау һәм өндәү җөмләләрдә берәр нәрсәне әшләми калырга, булдырмый калырга мөмкин түгеллеген белдерә. — *Озату хөрмәтенә, дисез,— алай дигәч, ничек сөйләмисең инде.* А. Шамов. —*Минем гайбәтемне саткан кешене ничек яратыйм.* Ә. Айдар.

3. Эш яки хәлнең сыйфаты турындагы сорауны белдерә. *Иртә торсаң, Няня килеп җитә: „Ни телисез, Кәеф ничек?" — дип.* Ш. Маннур.

4. Сокланууны, гаҗәпләнүне белдерә. [*Мостафин Нәҗиягә:*] *Карлыгачым, тышта эшләү сиңа ничек килешә, ничек син тагын да матурланып китәсең, — ди иде.* Ә. Еники.

5. Гадәттә *менә, әнә* сүзләре янында: алда сөйләнгән сыйфат һәм үзенчәлекне атамыйча, гомумиләштереп, аңа ишарә буларак кулланыла. *Сөембикә апа әйтә, сессиядә сөйләнгән сүзләр барысызга да тия, бер Нургали абый гына түгел, барысыз да тырышып эшләргә тиешсез, ди. Днә ничек бит ул!* Ә. Еники.

6. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр составында: 1) иярчен рәвеш җөмләне баш җөмләгә бәйли. *Кигән киемничек туза, Ясьь гомер шулай уза.* Җыр; 2) аергыч иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли *(нинди* мәгънәсендә). *Су өстендә дулкын ничек, Безнең шундый чагыбыз.* Җыр.

Ничек кирәк (җитте) алай — 1) көч-хәл белән, кыенлык белән. [*Хәдичә түти*] *баскычтан ничек кирәк алай менеп җитте дә уфылдап өйалды бусагасына килеп утырды.* Г. Бәширов; 2) аннан-моннан, җиңелчә генә, өстән-өстән генә эшләнгән. *Мин, ничек кирәк алай киенеп, Сибгатьләрнең атын илтергә --- чыгып киттем.* А. Шамов. **Ничек кенә** — 1) борчылуны аңлата. *Ничек кенә төшәрсең икән?* Д. Аппакова; 2) көчле теләкне белдерә. *Ничек кенә кулга төшерергә?!* **Ничек кенә эле** — берәр нәрсә артык яхшы булганда, бик яхшы үтәлгәндә, башкарылганда әйтелә; мактауны аңлата. [*Нәҗип:*] — *Кара, бу чыгым тай да тәртәгә кердемени инде? Хәлим елмаеп*

куйды: — *Ничек кенә әле!* Г. Гобәй. **Ничек тә, ничек (кенә) булса да** — барлык чараларны кулланып, нинди юл белән булса да. — *Сәләхине ничек тә терелтергә тырышыгыз инде.* Ш. Камал. — *Ничек кенә булса да, Мәрьямне дә күрергә кирәк.* Г. Ибраһимов. **Ничек тә бер** — кайчан да булса бер. *Ничек тә бер килермен әле.*

НИ'ЧЕКТЕР *а.* Ни сәбәптәндер (билгесезлекне белдерә). *Ничектер мин үземнең бик үк яшь бала вакытларымны хәтерли алмыйм.* М. Гали. *Кузгалып киткән чагында Нәфисә ничектер бик сагышлы, үтә борчулы кебек күренде.* Г. Бәширов.

НИ'ЧӘ *а.* **1.** Нәрсәнең дә булса күләмен, санын, микъдарын һ. б. белергә теләп сораганда кулланыла. [*Сәләхи:*] *Син миннән апа дип әйттермәкче буласың,* — *сиңа ничә яшь соң?* Ш. Камал. [*Якуб:*] *Шулай, Шәрифҗан. Мылтык тота белүче ничә кешең бар?* И. Гази.

2. *рәв. мәгъ.* Берничә, бик күп. *Ничә еллар буе хыялымда көтеп алган беренче эш көнем.* Г. Минский. [*Кадыйр*] *ничә тапкырлар бусага төбеннән кире борылды.* А. Алиш.

Ничә әйтсәң дә — ничек кенә булмасын, һәрхәлдә. *Ничә әйтсәң дә, бу бүрек* [*Габдулланың*] *ике ярым еллык Кырлай тормышының истәлеге иде бит.* Ә. Фәйзи. **Ничә җәйләр, ничә кышлар** — бик күп вакыт үтү турында. — *Кемне күрәм мин! Ничә җәйләр, ничә кышлар!* Ф. Әмирхан.

НИ'ЧӘЛЕ *а. сөйл.* Берәр нәрсәнең нинди номерлы булуын, размерын белергә теләгәндә кулланыла. *Ничәле галош? Ничәле фильтә?*

НИ'ЧӘЛӘП *а.* Чама белән күпме булуын белергә теләп сораганда кулланыла. *Ничәләп кеше булыр?*

НИ'ЧӘМӘ-НИ'ЧӘ *рәв.* Бик күп, әллә ничә. *Ничәмә-ничә гасырлар буе җилләр сызгырып торган --- бушлыкта хәзер тракторлар, комбайннар йөри.* А. Әхмәт. *Нәфисә бит* [*Наташадан*] *байтак нәрсә өйрәнде, ничәмә-ничә тапкыр киңәшкә килде.* Г. Бәширов.

НИ'ЧӘНЧЕ *а.* Нәрсәнең дә булса санау тәртибендә нинди урында торуын сорау өчен кулланыла; тәртип буенча, исәп буенча нинди яки кайсы урында. — *Бусы ничәнче булды?* Г. Гали. | *рәв. мәгъ.* [*Газинур*] *ничәнче кабат инде „эх, менә шундый кеше була алсаң иде!" дип сокланып куйды.* Г. Әпсәләмов. *Мин үземнең „кырык беренче" түгел, бәлки йөз дә әллә ничәнче шәкерт икәнемне белеп шатландым.* М. Гафури.

НИ'ЧӘСЕ *а.* Ай яки атнаның кайсы көне булуын белергә теләп сораганда кулланыла. *Сездә бүген ничәсе? Бездә кадер кичәсе.* Җыр. | *рәв. мәгъ. Ничәсе икәнен дә белгән юк.*

НИ'ЧӘШӘР *а.* **1.** Нәрсәне дә булса күпмешәр итеп бирү, алу һ. б. турында сораганда кулланыла. *Ничәшәр алма?*

2. Берничә мәртәбә, бик күп. *Киң Россиянең Уралын, Иделен, Донбассын, Себерен ничәшәр кат атлап үткән егетләрнең батырлыгын сөйләргә кереште* [*оратор*]. К. Нәҗми.

НИ'ЧӘШӘРЛӘП *а. к.* ничәшәр (1 мәгъ.).

НИ'ЧӘҮ *а. сөйл. к.* ничә (1 мәгъ.). — *Ничәү булыр икән,* — *Шәрифҗан күңеленнән саный башлады.* И. Гази. — *Әйт тизрәк, иптәшләрең ничәү?* Д. Аппакова.

НИШАН *и. иск. кит.* **1.** Билге, тамга, әз, галәмәт. *Һич калмады шаннан нишан, Калды дингә дошман ишан.* Г. Тукай.

2. Егет белән кызның бер-берсенә биргән вәгъдә бүләкләре (мәсәлән, балдак).

3. Бүләк, орден. *Бәгъзы аның суфыйдыр, бәгъзы ишан, Гүя Җәбраил китергән аңа нишан.* Ш. Мөхәммәдев.

НИШЛӘТҮ *ф.* Берәр үзгәрешкә дучар итү, берәр хәлгә төшерү. *Былтыр әнә алма сатучының кызы күңелне әллә нишләтеп китте бит.* Ф. Хөсни. *Ике доктор --- сәгать ярымнан артык юып, операцияләр ясап, әллә нишләтеп бетерделәр.* Ш. Камал.

НИШЛӘҮ *ф.* **1.** Эш-хәлне ачыкларга теләп сораганда кулланыла. [*Нәсимә:*] *Син нишлисең, дгъзам?* Р. Ишморат. — *Карышмыйм мин, Шәйхаттар бабай, ләкин ул чакта минем звеном нишли?* Г. Гобәй. || *рәв. мәгъ.* **нишләп.** Ни өчен, ни сәбәпле. — *Нишләп бу Гарәфи абзый бу кадәр йомшак?* Г. Әпсәләмов. [*Гашыйка:*] *Нишләп хат язмый ул, нишләп? Исәнме ул минем Әхмәдикәем?!* А. Әхмәт.

2. Нәрсә дә булса эшләү, берәр эш башкару. *Хуҗа малае белән бергә ике-өч бала, кызыксынып, шофёрның нишләгәнен карап торалар.* А. Шамов.

Нишлисең бит *кер. сүз.* — берни дә эшләп булмый дигән мәгънәдә. *Нишлисең бит, җаны теләгән елан ите ашаган, диләр.* М. Гали. *Нишлисең бит, ятим кеше булып үстек без.* Ә. Айдар.

НИЯТ *и.* **1.** Берәр нәрсә эшләр өчен алдан корылган уй-план; теләк. *Мәүлиха улының ниятен күптән сизеп йөри иде.* Г. Бәширов. *Эшнең башы — ният.* Әйтем.

2. *дини.* Берәр төрле теләк тормышка ашсын өчен, Хуҗа Баһаветдин (әүлия) исеменә багышлап дога уку. [*Мәгъри карчык:*] *„Закирның алай күңелсез йөргәнен ишетеп бик хафаландым", ди, Хуҗа Баһаветдин исеменә ният бирергә кушты.* Г. Камал.

Ният итү, ният кылу — уйлап кую, план кору. *Күрше агаебыздан бер алтатар сорарга кичтән ният итеп яттым.* Г. Тукай.

НИЯТЛӘНҮ *ф. к.* ниятләү (1 мәгъ). *Бригадаларны йөреп әйләнгәннән соң, Тимери, бөтен авылны аякка бастырырга ниятләнеп, кайтырга чыкты.* Г. Бәширов. [*Мохтар*], *иртәгә ял көне булганлыкны искә алып, --- җыелышка барып чыгарга ниятләнде.* Ш. Камал.

НИЯТЛӘҮ *ф.* **1.** Берәр эшне эшләргә, үтәргә дип уйлау, исәп итү, план кору. *Марат --- Гөлсем апаның ниндидер яхшы нәрсә ниятләгәнен сизенеп, аның муенына сарылды.* Г. Гобәй. *Мин шәһәрдә дә калмыйм, Урта Азиягә китәргә ниятлим.* А. Шамов.

2. Багышлау. *Зыя* [*намазлыкны*] *кыйблага каратып җәйде дә азан әйтте, соңра, атасының уң ягыннан торып, намаз ниятләде.* Г. Ибраһимов. — *Дүрт рәкагать фариз урынына өч рәкагать сөннәт ниятләгәнмен.* Т. Гыйззәт.

НИҺАЯСЕЗ *рәв. иск.* Иксез-чиксез, бик күп, очсыз-кырыйсыз. *Сандугачның ниһаясез гади булган сөю һәм моң белән тулган музыкасы — сайравы ишетелә.* Г. Ибраһимов.

НИ'ҺАЯТЬ **1.** *и.* Нәрсәнең дә булса очы, чиге, кырые, ахыры. □ *Мине ниһаяте булмаган бер --- [упкын] эчендә калдырып киттеләр.* М. Гафури.

2. *кер. сүз.* Ахыр чиктә. *Ниһаять, телефон шалтырады.* К. Нәҗми. || Тагын, шуның өстенә, өстәвенә тагын. *Арча кырының беренче йорт лары, Балык бистәсе, ниһаять, Печән базары чаты беренче тапкыр Казанга килүнең инде онытылып бара торган истәлекләрен яңартып җибәрделәр.* Ә. Фәйзи.

3. *с.* Чиктән тыш, көчле (зур һ. б.). *Күп вакытта бүлмәгә кереп утыргач та ниһаять дәрәҗәдә эчем поша.* Ш. Камал.

НИҺАЯТЬСЕЗ *рәв.* Иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз. *Ниһаятьсез караңгы, күзгә төртсәң дә күренмәслек.* М. Гафури.

НОВА'ТОР *и.* Берәр өлкәдә яңа идеяләр, принциплар, ысуллар уйлап чыгаручы һәм аларны тормышка ашыручы. *Биредә бүген хезмәт новаторлары җыелган.* Г. Минский. *Бер атнадан Москвада безнең министрлыкта стахановчы новаторлар киңәшмәсе була.* Р. Ишморат.

НОВА'ТОРЛАРЧА *рәв.* Новаторларга хас булганча. *Новаторларча эшләү. Новаторларча карау.*

НОВА'ТОРЛЫК *и.* Новатор эшчәнлеге; яңалык кертү эше. *Новаторлык белән формализм, - - - ике тәкә башы кебек, икесе бер казанга сыймый.* Г. Әпсәләмов. *Әлбәттә, Тукайның шигъри новаторлыгы билгеле бер җирлектә, билгеле бер традицияләр белән азыкланып мәйданга чыкты.* Г. Халит.

НОВЕ'ЛЛА *и.* Кыска повесть, зур булмаган хикәя. *Педучилищеда вакытта Каюм Насыйриның новеллаларын укыйлар иде.* М. Мәһдиев.

НОВЕ'ЛЛАЧЫ *и.* Новелла язучы.

НОВОКАИН *и. мед.* Авыртуны тоймаслык итү һәм дәвалау өчен кулланыла торган медицина препараты.

Новокаин блокадасы — периферик нервлар системасына новокаин эремәсе белән тәэсир итеп дәвалау методы. *Новокаин блокадасыннан соң авыруның бөерләре яхшырак эшли башлады.* Г. Әпсәләмов.

НОГЫТ, НУГЫТ *и.* Эре озынча орлык (борчак) бирә торган кузаклы бакча үсемлеге. || Шул үсемлекнең борчагы (орлыгы).

Ногыт борчагы — *к.* ногыт. *Борчак һәм ногыт борчагы җылыга таләпчән түгел.* Йорт эшләре. **Ногыт салу** — ногыт борчаклары белән күрәзәлек итү. *Мәрьям матур ногыт сала.* Дәрдмәнд. **Ногыт чыбыгы** *бот.* — вак, йомшак борчакка охшаган җимешле, тау битләрендә, чиялектә үсә торган куак; *русчасы:* бобовник. *Анда тау битендә сөергә дә, чабарга да ярамаган ташлы, чокырлы, ногыт, тубылгы чыбыклы тигезсез урыннар бар.* Г. Ибраһимов.

НОГЫТЧЫ *и. иск.* Күрәзәче, ногыт борчаклары белән күрәзәлек итүче.

НОКА'УТ *и. махс.* Бокста боксёрның, егылгач, ун секунд үткәнче аягына басып, көрәшне дәвам иттерә алмау хәле һәм җиңелгән дип саналуы. [*Касыйм*], *боксёрлар сугышка әзерләнгән кебек, йодрыкларын йомарлап, Нәҗип өстенә килә башлады: „Саклан, дустым, ике ударданнокаут ясыйм!“* Г. Ахунов.

НОКДА'УН *и. махс.* Бокста боксёрның, егылгач, ун секунд үткәнче торып, көрәшне дәвам иттерә алу хәле. *Андрей - - - Жоржның торуын көтте. Ул судьяның нокдаун санавын да, иптәшләренең шатланып кычкыруын да - - - ишетмәде.* Г. Әпсәләмов.

НОКСАН *и. иск. кит.* Җитешсезлек, кимчелек. *Күз алдыма ноксаным килә.* Г. Тукай. *Әгәр, ноксаннары белән бергә дә, әдәбиятыбызда артык нәрсәләрдән саналырга мөмкин түгелдер.* Ф. Әмирхан.

НОКТА *и.* 1. Берәр очлы нәрсә (энә, карандаш очы һ. б.) белән кагылудан калган эз, кечкенә генә түгәрәк төртке. [*Малай*] *акбурын бора-бора ике нокта төрттте.* Г. Гобәй. || *күч.* Күренер-күренмәс кенә, нинди дә булса бик кечкенә нәрсә. *Шул чакта офык читендә бер нокта күренде, тора-бара зур булды.* А. Алиш. *Бер көтү карга кызыл фонда кара нокталар булып кына селкенеп тора.* И. Гази.

2. Җөмләләрне бер-берсеннән аеру өчен һәм кыскартылган сүзләрдән соң куела торган тыныш билгесе (.).

3. Алгебрада, нота язуында, телеграф кодында, географик карталарда һәм планнарда шартлы билгеләү өчен кулланыла торган график тамга (.).

4. Геометрия, механика, физикада үлчәме булмаган урын, сызык кисемененң чиге. *Туры сызык белән ярым әйләнәнең кисешү ноктасы. Таяну ноктасы.*

5. Пространстводагы яки нәрсәнең дә булса өстендәге бер урын. *Мылтыклар бер ноктага карап аттылар.* К. Нәҗми. *Эйфель манарасы — җир шарында кеше кулы белән эшләнгән биек ноктаның иң биеге.* Г. Гали. || Берәр нәрсәнең, күренешнең һ. б. чиге, төп моменты. *Уйлаган эшем үз ноктасына җитмәгән әле.* Т. Гыйззәт. || *күч.* Дәрәҗә, чик. *Дәрнең кульминацион ноктасы.* □ *Кояш иң биек ноктасына җиткәч кенә, өметсезләнеп, хәлдән таеп кайтырга җыйналганда гына таптылар пулемётны.* Г. Гобәй. *Сугыш - - - иң кызу ноктасына җитте.* Ш. Усманов.

6. Берәр төрле пунктлар системасында яки челтәрендә нәрсә дә булса урнаштырылган, куелган урын. *Сәүдә ноктасы. Радиотапшыру ноктасы.* □ *Безнең тарафтан ясалган нөжүм дошманның моңа кадәр безгә билгесез ут нокталарын ачарга мөмкинлек бирде.* Ә. Айдар. *Турыдан, маңгайдан барып керү һич мөмкин түгел, - - - пулемет нокталарының куе булулары һич мөмкинлек бирми.* Ф. Кәрим.

7. *физ.* Матдәләрне бер хәлдән икенче хәлгә әверелдерә торган температура. *Кайнау ноктасы. Бозга әйләнү ноктасы.*

◇ **(Бер) ноктага карап тору (текәлү)** — нинди дә булса урынга юнәлгән хәрәкәтсез күз карашы белән карау. *Галия күзләрен һаман шулай ниндидер билгесез ноктага текәгән килеш басып тора иде.* А. Шамов. *Рәхим, урындыкка утырган килеш, бер ноктага карап трубкасын тартып тора.* Һ. Такташ. **Нокта кебек (төсле)** — бик кечкенә нәрсә турында. *Нокта төсле нәни кызыл бөжәк Менеп килә чәчәк очына.* Ш. Маннур. **Нокта кую** — 1) нинди дә булса эшне төгәлләү, тәмам итү. *Хөрмәтле укучы, рөхсәт итегез шушы урында нокта куярга.* Ә. Еники; 2) араны өзү, һәртөрле мөнәсәбәтләрне өзү. *Дуслыкка нокта кую.* **(Бер) ноктаны да калдырмый, ноктасына кадәр** — бөтен ваклыклары, төгәлликләре белән; җентекләп. *Гөлбикә, бер ноктаны да калдырмыйча, тулы бөтен күренештә сөйләп бирде.* Г. Ибраһимов.

НОКТАЛЫ: ноктаны бегония *бот.* — яфракларында кәмеш сыман ноктаны бизәкләр булган ал чәчәкле декоратив үсемлек. **Ноктаны өтер** — тезмә кушма яки үз эчендә өтере булган тиндәш кисәкле җөмләләрдәге җәенке, азмы-күпме төгәлләнгәнрәк мәгънәле кисәкләрне аеру өчен куела торган, нокта белән өтердән гыйбарәт тыныш билгесе.

НОКТЮРН *и. муз.* Зур булмаган лирик музыкаль әсәр. *Шопен ноктюрны.*

НОЛЬ, НУЛЬ *и.* 1. Зурлыкның булмавын белдерә торган 0 санының билгесе. Теләсә нинди санның уң ягына куелып, аның ун мәртәбә зураюын белдерә.

2. Нәрсәнең дә булса чагыштырмача температурасын күрсәтә торган шартлы билге. *Ноль градус. Температура нольдән төшү.*

3. *күч.* Җәмгыятьтә бернинди урын алып тормаган яки берәр кеше каршында әһәмияте булмаган, түбән, начар кеше турында. *Син кемгәдер кирәк. Син бу тормышта нуль түгел.* М. Мәһдиев.

Ноль-ноль — 1) вакыт турында әйткәндә: төгәл сәгатьне белдерә, бер минут соң да, алдан да түгел дигән мәгънәдә кулланыла. *Ике сәгатьтән, ягъни егерме бер сәгать ноль-нольдә мин нәкъ шушы [урынга килеп җитәм].* Каз. утл.; 2) *спорт.* бер якның

да җиңмәве белән беткән уенның нәтиҗәсен белдерә (очко язылмаган очракны).

НОМЕНКЛАТУ'РА *и.* 1. Нинди дә булса белгечлек, техника, производство һ. б. ш. өлкәләрдә кулланыла торган атамалар җыелмасы, терминнар исемлеге. *Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясындагы төрләрне исемләү номенклатурасы.*

2. Кадрлары югары партия, совет, профсоюз оешмалары тарафыннан билгеләнә торган эш урыннары исемлеге.

НОМЕНКЛАТУ'РАЛЫ *с.* Номенклатурага (2 мәгъ.) караган, номенклатура (2 мәгъ.) булып саналган. *— Төрле хуҗалык һәм культура оешмаларында номенклатур[алы] урыннарда байтак утырганым бар.* С. Сабиров.

Номенклатуралы хезмәткәр — хезмәт урынына югары инстанцияләр тарафыннан персональ рәвештә билгеләнә яки раслана торган кеше.

НО'МЕР *и.* 1. Тиндәш (бер иш) предметлар рәтенең тәртип саны. *Квартира номеры. Телефон номеры.* □ [*Утеп баручы*] *Госман тора торган йорт номерын сорады.* А. Шамов.

2. Нинди дә булса цифр язылган планка, ярлык, регистрацияләнүне белдерә торган документ һ. б. *Табель номеры. Велосипед номеры.* □ *Эшчеләр санын, номерлар тагып, Меңәрләп кенә саныйлар анда* [*шахтада*]. К. Тинчурин. *Ул арада староста, канцеляриядән номер алып чыгып, егетләргә --- өләште.* М. Гали.

3. *к.* сан I (3 мәгъ.). *Редакцияләрдә газеталарның яңа ел номерлары әзерләнә.* Г. Минский.

4. Гостиницада, мунчада һ. б. аерым бүлмә. *Ул бер кешелек тар гына номерда ята иде.* Г. Әпсәләмов. [*Мәрфуга*] *гостиница номерына килеп җиткәнче әнисенә сүз катмады.* Г. Ахунов. || *иск.* Гостиница. *— Әле мин ашамаган, безнең номерда кухнялар ябылгандыр.* Г. Камал. *Без торган номер --- уртача гына бер номер иде.* Г. Тукай.

5. Концерт, кичә һ. б. ш. ның аерым башкарыла торган бер өлеше. *Концерт өчен оригиналь номерлар уйлап чыгардылар.* Г. Гобәй. *Программа ярыйсы гына, бик төрле номерлардан төзелгән.* Ш. Камал.

6. *куч. сөйл.* Берәр көтелмәгән хәл, вакыйга турында. *Казан округындагы бунтлар, Алафузовтагы забастовка, тимер юлчыларның бер көнге номерлары—барысы да* [*большевиклар*] *эше.* К. Нәҗми. *Берике ел элек Сабирның шактый хәтәр номерлары булды.* М. Мәһдиев.

7. *хәрби.* Орудие, пулемет һ. б. расчетындагы сугышчы. *Икенче номер пулемётчы Сабиров Шаяхмәтнең уң ягында ята иде.* А. Әхмәт.

НО'МЕРЛАУ *ф.* Номер кую, номер сугу. *Номерлап тезелгән формаларны нечкәлек белән өйрәнергә кирәк.* Г. Ибраһимов.

НО'МЕРЛЫ *с.* Номеры булган, номер куелган, номер сугылган. *Беренче номерлы шахтаның җимерелүен хәбәр иттеләр.* М. Гафури.

НОМИНАЛ *и. махс.* Кыйммәтле кәгазь, кәгазь акча һәм товарларның өстенә язып куела торган хакы. *Номинал буенча сату.*

НОМИНАЛЬ *с. махс.* 1. Берәр нәрсәнең өстендә акча бәясе белән күрсәтелгән, акча бәясе белән билгеләнгән. *Номиналь бәя. Номиналь эш хакы.*

2. Исеме генә булып, чынлыкта булмаган; ялган. *Номиналь җитәкче.*

НОМИНАТИВ *с. лингв.* Атау, исемләү өчен хезмәт итә торган. *Сүзнең номинатив функциясе. Номинатив җөмлә.*

НОМОГРА'ММА *и. мат.* Төрле исәпләүләрдә кулланыла торган геометрик зурлыклар графигы. *Таяк сыман яшен уздыргычларның биеклеген махсус номограммалар ярдәмендә табалар.* Яшен.

НОНПАРЕЛЬ *и. махс.* Петиттан ваграк шрифтның атамасы.

НОРВЕ'ГИЯЛЕ *с.* Норвегиядә яшәүче.

НОРД *и. махс.* 1. Төньяк, төньяк юнәлеше.

2. Төньяктан исә торган җил.

НОРД-ВЕСТ *и. махс.* 1. Төньяк-көнбатыш, төньяк-көнбатыш юнәлеше.

2. Төньяк-көнбатыштан исә торган җил.

НОРД-ОСТ *и. махс.* 1. Төньяк-көнчыгыш, төньяк-көнчыгыш юнәлеше.

2. Төньяк-көнчыгыштан исә торган җил.

НО'РМА *и.* 1. Нәрсәнең дә булса гадәттәге, гомуми кабул ителгән, мәҗбүри булган тәртибе, торышы. *Үз-үзеңне тоту нормалары. Әдәби тел нормалары.*

2. Берәр нәрсәнең булырга тиешле үлчәме, күләме. *Явым-төшем нормасы. Эшләп чыгару нормасы.* □ *Мин бодай участогында чәчү нормасын, агроном өйрәткәнчә, туфракның сыйфатына, орлыкның авырлыгына --- карап билгелим.* Г. Бәширов. *Эшнең сыйфаты өчен дә, норма өчен дә бригада җавап бирә иде.* Р. Ишморат.

Нормага керү — 1) норма булып китү; 2) гадәти халәткә керү, нормаль хәлгә кайту.

НО'РМАЛАНУ *ф.* Нормага салыну, нормага китерелү.

НО'РМАЛАУ *ф.* Берәр нәрсәнең нормасын билгеләү, аны чикләү. *Сугыштан соңгы авыр еллар иде. Икмәкне карточка белән нормалап кына бирәләр.* А. Расих.

НО'РМАЛАШТЫРУ *ф.* Норма билгеләү, норма кую. *Хезмәтне дөрес нормалаштыру җитештерү процессы белән идарә итү өчен әһәмиятле шартларның берсе булып тора.* Политэкономия.

НОРМАЛЬ *с.* 1. Нормага туры килә торган; нинди булырга тиеш булса, шундый; гадәттәге, табигый. *Кешеләр арасында бераз нормаль хәлгә кайткан кебек булдым.* Ә. Еники. [*Гафур:*] *Кая, пульсыңны тотып карыйм әле, каениш. (Мирсәетнең кулын тота). Нормаль.* Р. Ишморат.

2. Психик яктан сәламәт булган. *Нормаль кешеләр.*

НО'РМАЛЫ *с.* 1. Нормага салынган, норма куелган, норма белән билгеләнгән. *Нормалы эш.*

2. Кирәк кадәр генә, нормадан арттырмыйча, тиеш булганча. *Нормалы ашау. Нормалы йоклау.*

НОРМАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Нормаль хәлгә китерү.

НОРМАННАР *и.* VIII—XI гасырларда Европа илләренә талау һәм басып алу максаты белән походлар ясаган төньяк герман кабиләләре. *Норманнар Скандинавия ярымутравының яр буйларында һәм хәзерге Данияда яшәгәннәр.* Урта гас. тарихы.

НОРМАТИВ I *и.* Берәр төрле эш башкару өчен билгеләнгән нормалар күрсәткече. *Техник нормативлар.*

НОРМАТИВ II *с.* 1. Нормага туры китереп куелган, норма буенча билгеләнгән. *Детальләрнең нормативлар запасы.*

2. Нәрсәнең дә булса нормасын, кагыйдәләрен билгели торган. *Норматив грамматика.*

НОРМИРО'ВЩИК *и.* Нормалаштыручы, нормалар билгеләүче.

НОРСУЛЬФАЗОЛ *и. мед.* Бактерияләр китереп чыгара торган авыруларны дәвалау һәм температураны төшерү өчен кулланыла торган дару препараты. *Әнисе* [*Светланага*] *аспиринын, норсульфазолын, тагын нәрсәләрнедер әчерде дә, урынга яткырып, өстенә кат-кат япты.* Л. Ихсанова.

НОСИ'ЛКА *и.* Авыр әйберләрне яки кешеләрне урыннан урынга күчереп йөртү өчен кулланыла торган җайланма (гадәттә такта җәелгән яки тукыма тарттырылган ике параллель таяктан тора). *Янмый торган бик күп башка вагоннардан носилкалар белән яралы кешеләрне ташыйлар иде.* Г. Гобәй. *Мөхетдин карт белән Мәгъсүм ындыр табагының икенче башына без селеккән саламны носилка белән ташып торалар.* М. Гали.

НОСИ'ЛЬЩИК *и. сөйл.* Вокзал, пристаньнарда багажларны ташып, күчереп йөрүче кеше. *Хәйрулла абзый уникә сәгать хезмәт итеп кайта да, ашап-эчкәч, вокзалда носильщик булып эшләргә чыгып китә.* А. Шамов.

НО'ТА I *и. муз.* 1. Музыкаль авазны күрсәтү өчен шартлы график билге.

2. Музыка һәм җырда — аваз үзе. *Көннәр узу белән бу көйләр, бу моңнар илгә көч бирү, илне баету ноталарына әйләнәләр.* Г. Кутуй.

3. Шартлы график билгеләр белән язылган музыкаль әсәр тексты; шундый текстлардан торган дәфтәр, китап һ. б. *Раушания нотага карап Шопен музыкасын уйный.* Р. Ишморат. *Фатыйма, рояль янына утырып, ноталар сайлады: аннан соң залда „Фауст" музыкасыннан бер кисәк яңгырады.* Ф. Әмирхан.

4. *күч.* Нинди дә булса тойгыны, хисне белдерә яисә кемгә яки нәрсәгә карата берәр төрле мөнәсәбәтне күрсәтә торган тон, сөйләү интонациясе. *Ул сүзен кабатлаганда, Садыйк картның тавышында үчегү, җәберсенү нотасы ишетелде.* Ш. Камал.

Нотага салу — музыкаль әсәрне шартлы график билгеләр белән язу. **Нота станы** — ноталар язу өчен кулланыла торган параллель горизонталь биш сызык. *Нота станы, ноталарның ишетелү югарылыгын билгеләп, ноталар язу өчен кулланыла.* Э. Бакиров.

НО'ТА II *и. махс.* Бер ил хөкүмәтенең икенче ил хөкүмәтенә язма рәвештә җибәргән рәсми дипломатик мөрәҗәгате.

НОТАБЕ'НА, НОТАБЕ'НЕ *и.* Тексттагы берәр фикергә укучының игътибарын ныграк юнәлтү өчен, китапның яки берәр документның читенә куела торган *NB* билгесе.

НОТАРИАЛЬ *с.* Юридик актларны раслауга, документлардагы һәм аларның копияләрендәге имзаларның дөреслеген таныклауга бәйләнешле. *Нигъмәт әле күптән түгел генә укып кайтып, нотариаль конторада эшләргә тотынган иде.* Г. Гали. || Нотариуста таныклынган. *Нотариаль күчермә.*

НОТА'РИУС *и.* Актларны, килешү кәгазьләрен, документларның копияләрен һ. б. рәсми рәвештә таныклап торучы хезмәткәр. [*Лотфулла:*] *Максим, менә нәрсә киңәш итәм: документларыңның копиясен алып, нотариустан раслата тор.* Г. Ахунов.

НОТИФИКА'ЦИЯ *и. махс.* Нинди дә булса дәүләткә, дипломатик ведомствога һ. б. нота белән берәр нәрсә белдерү, берәр нәрсә турында хәбәр итү.

НОТЫК *и. иск.* Речь. *Озын сөйләүче мөгаллим, һәр мәсьәлә куелган саен, өчәр, дүртәр сәгать нотык сөйләгән.* Һ. Такташ.

НОЯБРЬ *и.* Календарь елның унберенче ае. *Менә хәзер ноябрьның беренче атнасы инде, көннәр исә һаман да коры әле.* Г. Бәширов. *Ноябрь чыгып җиткәне юк әле, шулай да дөнья кар туфаны астында калып, җир йөзен тирән көрт басты.* Г. Ибраһимов.

НУ *ы. сөйл.* 1. Нәрсә дә булса эшли башларга өндәүне белдерә. — *Ну, Ильяс, давай, сызганып эшләргә кирәк.* М. Әмир.

2. Ис китү, гаҗәпләнү яки ризасызлык, канәгатьсезлек, ирония хисләрен белдерә.—*Ну, Булат малай, егет икәнсең, йөрәктәгене әйттең дә салдың бит.* К. Тинчурин.— *Ха-ха-ха... Ну тел синдә хәзер, әй.* Г. Гобәй.

3. Сорау җөмләнең башында килеп, берәр эш-хәлдән соң киләчәктә нишләячәк турында сорауны белдерә.— *Ну, Камил, хәзер ни эшлисең инде, укырга каласыңмы?* Һ. Такташ.

4. Йомгак яки кереш ясауны белдерә.— *Ну, ярый, мин гыйшык тотам, ди.* Ә. Айдар.— *Ну, Фәез дус, хәзер бөтен эш синдә инде.* Ш. Усманов.

НУГАЙ *и.* 1. Төньяк Кавказда, Ставрополь өлкәсендә, Дагстан АССРда яши торган төрки халык һәм шул халыкның бер кешесе. *Булдым Дагстан чүлләрендәге кара нугайлар арасында.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шуның белән бәйләнешле.

2. *к.* татар. *Борылып аккан су буйларын тугай диләр, Төркстанда татарларга нугай диләр.* Шура.

Нугай камчысы *диал. бот.* — *к.* шайтан таягы.

НУЖА *и. сөйл.* 1. Яшәү өчен иң кирәкле булган нәрсәләрнең җитешмәве, юк дәрәҗәсендә булуы, мохтаҗлык; ярлылык, фәкыйрьлек. *Әнкәем нужадан үлде.* Г. Толымбай. [*Миңнулла:*] *Безнең ише атсыз да, тунсыз да кешеләрнең нужасы башкарак: ат кирәк безгә, ат!* И. Гази.

2. Мәшәкать, авырлык, кыенлык, читен хәл. *Егетнең яхшысы төрле нужага ярый.* Мәкаль. [*Шәйхи абзый белән Сәетгали*] *солдат нужасын бергә татып, бергә йөргәннәр.* Ә. Еники.

◇ **Нужа калачы ашау** — кыенлык кичерү, авырлык күрү. **Нужа камыты** — мохтаҗлык, кыенлык. *Кем генә патша булса да, муеныбыздан нужа камытын салдырмас.* Х. Кәрим. **Нужа күрү (чигү)** — төрле авырлыклар, мохтаҗлыклар күрү, төрле кыенлыклар кичерү. *Нужа чигеп ятим үскән ярлы кызның язмышында әле яңа гына башланган иң якты сәхифәләрнең беренчесе иде бу.* А. Гыйләҗев. **Нужа печән ашата**— 1) теләмәгән кешегә ялынырга мәҗбүр булу турында; 2) белмәгән нәрсәне өйрәнергә мәҗбүр булу турында. **Нужадан чыкмау** — өзлексез мохтаҗлыклар кичерү, авырлыклар күрү, авыр тормышта яшәү. [*Сибай*] *нужадан чыкмады, җиләктәй яшь чагында сөйгән кызына өйләнә алмыйча, гомергә үкенечкә калды.* Г. Бәширов.

НУКТА *и.* Авызлыксыз йөгән (ат, бозау һ. б. ш. ны бәйләп, арканлап кую өчен). *Сыйлап-сыйпап, ялыннан, тамак астыннан иркәләп,* [*ат*] *башына озын, калын тезгенле каеш нуктаны кидерделәр.* Г. Ибраһимов.

НУКТАЛАУ *ф.* Нукта кидерү. *Тотарсың син аны, нукталарсың, атланырсың, алып кайтырсың.* Ш. Маннур.

НУКТАЛЫ *с.* Нуктасы булган, нукта кидерелгән. *Су буенда акбүз атлар Бар да каеш нукталы.* Җыр.

НУМЕРА'ТОР *и. махс.* 1. Тәртип номеры суга торган аппарат (мәсәлән, квитанцияләргә, накладнойларга һ. б. ш.).

2. Электр звоногында кайда басып шалтыратырга кирәклекне күрсәтә торган җайланма, прибор.

НУМЕРА'ЦИЯ *и. махс.* Эзлекле тәртиптә урнаштырылган предметларны цифрлар белән билгеләү, тәртип саны куеп чыгу эше.

НУМЕРА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Номер сугу, тәртип саны кую.

НУМЕРЛАМА *и. иск. к.* нумерация.

НУМИЗМАТ *и.* Нумизматика белгече; борынгы акча тәңкәләрен һәм медальләрен җыю, коллекцияләү

белән шөгыльләнүче кеше. *Габбас борынгы заман акчалары җыю белән мавыга, кыскасы, нумизмат иде.* В. Монасыйпов.

НУМИЗМА'ТИКА *и.* 1. Борынгы тәңкәләрне һәм медальләрне өйрәнә торган фән.

2. Борынгы акча тәңкәләрен һәм медальләрне җыю, коллекцияләү. *Иске акчаларга юлыксаң, миңа сал. Нумизматика белән шөгыльләнәм.* А. Гыйләҗев.

НУМИЗМА'ТИК *с.* Борынгы акчалар һәм медальләр җыюга, коллекцияләүгә караган. [*Болгар хәзинәләренең*] *кыйммәте нумизматик материалларга гына кайтып калмый, монда халкыбызның данлы, чал тарихын яктыртырга юл ачкан материаллар бар.* А. Расих.

НУР *и.* 1. Нинди дә булса яктылык чыганагыннан сузылган яки ялтырап торган предметтан чагылган яктылык сызыгы. *Елга өстендә кояш нурлары уйный.* А. Шамов. *Тулган ай, үзенең моңсу нурларын урманнар, кырлар өстенә чәчеп, әкрен генә йөзә.* Г. Әпсәләмов. || *күч.* Берәр нәрсәнең тиз арада, көтелмәгәндә күренеп китүе, чаткысы. *Өмет нуры. Бәхет нуры.*

2. *күч.* Ачыклык, мөлаемлык, җылылык (күздә, йөздә). [*Кызның*] *йөзендә ниндидер нур балкый төсле күренә иде ул минутта.* М. Әмир. *Ул карт инде, Ул борчылган, Нурын җуйган зәңгәр күзләре.* Ф. Кәрим.

3. *физ. күпл.* Кисәкчекләр яки электромагнитик тирбәнүләр агымы. *Рентген нурлары. Катод нурлары.*

◇ **Нур китү, качу (йөзеннән, күзеннән)** — нуры бетү, нурын югалту, томанлану. — *Кинәт күгәрендең, күзләреңнең нуры китте, үләсең икән дип торабыз.* Г. Гобәй. **Нур сибү (чәчү)** — төрле якка нур тарату, чыгару. *Кышкы төн. Киң күк йөзендә Ай көлә, нурлар чәчеп.* Н. Исәнбәт. *Ерактан ал таң сызыла, Офыкка сибеп нурын.* Ә. Исхак. **(Йөзендә) нур уйнау** — ачык күңелле, якты йөзле, көләч, шат булу турында. *Йөзләрендә нурлар уйный, Куймыйм туры кәраргә.* Җыр. **Нур өстенә нур (булу)** — берәр уңай нәрсәгә, уңай күренешкә икенче бер уңай нәрсә, уңай күренеш өстәлү турында. [*Нәфисә Гөлзәбәргә:*] *Әйтсәнә шуны, кырдагы игеннәрем белән бергә үз күңелем дә чәчәк атса, бу соң нур өстенә нур гына булачак түгелмени!* Г. Бәширов.

НУРАНИ *с. иск. кит.* Нурлы, якты, ялтыравыклы. || *рәв. мәгъ.* Нур белән яктыртып. [*Шакирның*] *җуялтылган[ы] йөрәкнең тышындагы нәрсә түгел, бәлки аның эчендәге, бервакытларда аны нурани тутырып торган тойгысы иде.* Ф. Әмирхан.

НУРЛАНДЫРУ *ф.* 1. Берәр кешене яки әйберне яктырту, нурга күмү. *Без һәр кичне, күккә йолдыз чыккач, Эзләп таба идек аларны; Икесе дә якты яна иделәр, Нурландырып зәңгәр һаваны.* Ш. Маннур.

2. *күч.* Ачыкландыру, мөлаемландыру, матурлык, ямь, нур бирү (йөзгә). *Һәм бу „чал" аны тагы да матурлап, тагы да нурландырып җибәргән иде.* Г. Гобәй. || *күч.* Илһам, дәрт, көч бирү. *Газинурның күңелен шул туганлык мәхәббәтенең җылысы нурландыра иде.* Г. Әпсәләмов. *Әле хәзергә кадәр алар минем тереклегемне нурландырып торудан туктамыйлар.* Ф. Әмирхан.

НУРЛАНУ *ф.* 1. Нур чыгару, нур чәчү, яктырту. *Таң йолдызы гына һаман шулай нурланып җемелдәп тора.* А. Шамов. *Күрде кырда: бик матур бер әллә нәрсә ялтырый, Нурлана, җем-җем итә, йолдыз шикелле калтырый.* Г. Тукай.

2. Нурларны үзенә йоту, нурларга туену. *Нурлану, яки туфракның кояштан килгән җылы нурларны сеңдерә алуы* [*туфракның*] *төсенә бәйле.* Җир һәм туфрак.

3. *күч.* Җанлану, мөлаемлану, яктыру (күз, йөз). *Хатны укыган саен, Екатерина Павловнаның сагышлы йөзе яктыра, нурлана барды.* Г. Әпсәләмов. *Ансыз да матур зур күзләре бөтенләй ачылып, нурланып уйныйлар.* Г. Ибраһимов.

НУРЛАНЫШ *и.* Нурлы энергия чыгу, нурлы энергия таралышы. *Нурланыш хасил булу. Яктылык нурланышы. Яшен нурланышы.*

НУРЛАУ *ф.* 1. Яктырту, нурга күмү. *Кояш гүя алтын герб, Калка дөньяны нурлап.* З. Мансур.

2. *күч.* Берәр кеше яки әйберне ямьләү, матурлау, бизәү. *Һаваны — йолдыз, ирләрне — сакал, хатынкызны чәч нурлый.* Мәкаль.

НУРЛЫ *с.* 1. Нур чәчеп торган, нурга күмелгән. *Вакыт-вакыт нурлы күк йөзен ишелеп аккан болытлар каплап ала.* Ә. Еники. *Кояш чыкканда искиткеч матур, искиткеч нурлы иде.* А. Шамов. || *күч.* Шатлыклы, бәхетле. *Нурлы киләчәк. Нурлы хыяллар.* □ *Вакыт җитте, төн үтте, өстебезгә нурлы таң атты.* М. Гафури.

2. *күч.* Ягымлы, матур, көләч (йөз, күз һ. б.). *Ул үзенә якын ук килгән чибәр кызның нурлы, ягымлы йөзенә күтәрелеп карады.* А. Әхмәт.

НУРЛЫЛЫК *и.* Нурлы булу. *Таңның нурлылыгы, сөекле гөл чәчәгенең матурлыгы сандугачны шулкадәр җанландырган.* Ф. Әмирхан.

НУРСЫЗ *с.* 1. Карангы, күңелсез. *И сеңелем, җирегез бигрәк тә нурсыз күренә.* Д. Аппакова.

2. Нуры (2 мәгъ.) сүнгән, ялтыраусыз, җансыз, бернинди дә хис белдерми торган. *Аның төсе сулган, күзләре нурсыз, йөзе кыйшайган.* Ш. Камал. *Керфекләре көйгән нурсыз күзләр.* М. Җәлил.

НУРСЫЗЛАНУ *ф.* 1. Нурын (2 мәгъ.) югалту, сүнү. *Бөкрәйгәндер биле, нурсызланган күзе.* Г. Тукай.

2. Төссезләнү, нур чәчми башлау. *Күк итәкләре шактый агарган, ә ай, куркып калган кеше йөзе кебек, нурсызланган иде.* А. Шамов.

НУТ *и. бот.* Кузаклылар семьялыгына керә торган үсемлек (орлыгын ашамлык һәм хайваннар азыгы итеп файдаланалар). *Безнең илдә кузаклылардан яшелчә һәм басу культуралары арасында аерата борчак, фасоль, --- нут һәм кайбер башка үсемлекләр киң таралган.* Ботаника.

НУ'ТРИЯ *и. зоол.* Кимерүчеләр отрядыннан көрән төстәге кыйммәтле мех бирә торган җир-су җәнлеге. *Елга һәм күл буйларында нутрия --- бар.* Дөнья кис. геогр. || Шул җәнлекнең мехы.

НУХ: Нух (пәйгамбәр) заманыннан — бик күптәннән, борын заманнан. — *Минем кибеттә Нух пәйгамбәр заманыннан калган ситсы бар иде.* Г. Тукай. **Нух каргасы** — ялган мәгълүмат бирүче кеше. [*Хаҗи:*] *Иң кирәкле сүзне әйтмәгән бит, әкият. Их, Нух каргасы! Менә ышан син аңа!* Ш. Камал. **Нух көймәсе** — мифология буенча, имеш, бөтен дөньяны су басканда Нух пәйгамбәр үзенең семьясы һәм хайваннары белән котылып калган зур көймә. *Барсам, Нух пәйгамбәр көймәсеннән төшеп калган чапан дип уйларлык бер чапан кигән мулла утырган.* Г. Тукай.

НЫГУ *ф.* 1. Ныкка, чыдамлыга әйләнү, чыныгу. *Тары үсте, ныгыды.* М. Җәлил.

2. Сәламәтләнү, яңадан көч керү, хәл җыю. [*Фәтхи Мәдинәгә:*] *Бу хат синең кулга барып җиткәнче, бөтенләй ныгып җиткән булырсың дип уйлыйм.* Ш. Камал. *Мин инде тәмам сәламәтләндем, ныгыдым.* Ә. Айдар. || Көч, энергия керү, үсеп җитү. *Әллә буын яшькә күкрәк юка, әллә куллар ныгып җитмәгән.* Ш. Маннур. *Мускуллары ныгып җитмәгән һәм ул эшкә өйрәнмәгән Габделкаюм өчен көне буе балта тотып агач юну бик авырга килде.* М. Гали. || Тагы да куәтләнү, көчәю. *Яшәрде безнең ил, ныгы-*

ды. Ә. Ерикәй. *Бөек Ватан сугышы башлангач, алар арасында якынлык тагын да тирәнәя, ныгый төште.* Ә. Еники. || Көчләрне туплау. [*Безнең бурыч*] *авылда ныгып калып, безнең әре көчләребез килеп җиткәнгә кадәр дошманның барлык контратакаларын кире кагу.* И. Гази. *Кызыл Армия, Чарджоу тирәсендә ныгып, акларны каршы алды.* Ш. Усманов.

3. Тагы да көчәя төшү, көче, интенсивлыгы арту (җил, тавыш һ. б. турында). *Сөйләгән саен аның тавышы ныгый.* А. Шамов. || Үзгәрмәслек булып, нык булып урнашу, катгый фикер туу (карар, уй һ. б. турында). *Халыкның безгә ышанычы ныгыганнан-ныгый бара.* Ф. Бурнаш. *Чана юлы төшүгә ышаныч тәмам ныгып җиткәч, Бәдри абзый атны кунак чанасына җикте.* Ә. Фәйзи.

НЫГЫТМА *и.* **1.** Оборона корылмасы; оборона корылмалары булган урын. *Бөтен көнбатыш инженерлары кулы белән салынган тимер-бетон ныгытмалары көлгә әйләнеп күккә очалар.* Т. Гыйззәт. *Кар тирән һәм шәһәрнең ныгытмасы шәп булганга күрә, һөҗүм ясалганы юк.* М. Галәү.

2. Нәрсәне дә булса ныгытып, беркетеп кую өчен булган җайланма. *Чаңгы ныгытмалары.*

НЫГЫТУ *ф.* **1.** Нәрсәне дә булса кадаклап, кысып бәйләп, беркетеп кую. [*Нигъмәтҗан*] *өенең тәрәзәләрен, ишекләрен ныгытты, утын хәзерләде.* Ә. Фәйзи. *Минһаж, колаклар туңмасын дип, бүрекне басты, чабата бавын ныгытты.* Г. Ибраһимов.

2. Яңадан көч туплау, хәл җыю; чыныктыру. *Ә биш көннән көчне ныгытып, Авылларга кайтып китәрбез.* һ. Такташ. || Тагы да үстерү; яхшырту, зурайту. *Без тынычлык нигезен ныгытабыз, Моны һәркем белә дөньяда.* Ә. Ерикәй. *Кан-ут кичеп, дуслыкны ныгыттык без.* М. Җәлил. *Авыр чаклар, шөкер, узып бара, Ныгытабыз авыл дөньясын!* З. Мансур. || Өстәмә көчләр белән сан һәм сыйфат ягыннан берәр нәрсәне үстерү, көчәйтү; камилләштерү. *Кадрлар белән ныгыту.* □ [*Нәфисә*] *бригадасын ныгыту өчен көздән бирле ниләр генә эшләмәде!* Г. Бәширов.

3. Ныклы карарга килү. *Соңгы тапкыр Хикмәт, тагын бер кат, Тагын бер кат фикерен ныгытты:— Көч сынарга!* Ш. Маннур.

4. Ирешелгән нәрсәне, үзгәрмәслек итеп, ныклы хәлгә китерү, тотрыклы итү. — *Җиңүне аны менә монда ныгытырга кирәк, хезмәт фронтында.* Р. Ишморат.

5. *рәв. мәгъ.* **ныгытып.** Бик нык кисәтеп, кат-кат аңлатып, катгый рәвештә. [*Нәсимә Җәләлгә:*] *Син Камиләгә ныгытып әйтсәң, ул синең сүзеңә күнәр.* Ш. Камал.

НЫГЫТУЧЫ *и. махс.* Ныгыту эшләре белгече, тау эшчесе; *русчасы:* крепильщик.

НЫК *с.* **1.** Өзүе, ватуы, сындыруы һ. б. авыр, кыен булган, таза эшләнгән. *Маскировканың җебе һаман җитәрлек нык түгел төсле күренде.* Г. Гобәй. [*Бәдри:*] *Бу бишмәт бик нык булды инде.* М. Гафури. || Ертылмаган, тузмаган, бөтен (аяк киеме, өс киеме һ. б. турында). *Ныграк капчык эләксә дә, шатлыгыннан бер атна авызын җыялмый йөри ул.* Ш. Камал.

2. Көчле, сәламәт, чыдам. *Нык организм. Нык карт.* □ *Шулай да ныкәген икән үзе* [*Абдулла*] *бичара. Ярасы шундый каты булса да, һаман тел-дән калмады.* Г. Ибраһимов. *Хәлим ябыграк булса да, әре сөякле, нык тәнле, каты куллы малай.* И. Гази. || Көчле, яңгыравыклы (тавыш турында). *Тавышы нык, ышанычлы иде.* М. Әмир.

3. *күч.* Рухи яктан көчле, түземле, какшамас. *Һәрвакыт күтәренке күңелле, бер төрле авырлыкка да бирешми торган нык кеше --- сугыш вакытында район белән җитәкчелек итүнең кыенлыгын үзе генә белә иде.* Г. Бәширов. *Күңеле нык кешедән чир үзе качар, күңеле йомшак кешегә юк чир дә тагылыр.* Г. Әпсәләмов.

4. Ышанычлы, таянырга мөмкин булган, җитди, төпле. *Нык сүз.* □ [*Исмәгыйль Бәдригә:*] *Аларның вәгъдәләре нык.* М. Фәйзи. *Болай бары тик киң күңелле, бүгенгесе һәм киләчәгә нык, ышанычлы булган кешеләр генә көләләр.* Г. Әпсәләмов.

5. Бик көчле дәрәҗәгә җиткән, каты (җил, салкын турында). *Бер көн төш алдында, беренче неводны чыгаргач, нык кына җил кузгалды.* Ш. Камал.

6. *сөйл.* Бай, таза, зур мөмкинлекләре булган. *Нык хуҗалык.*

7. *рәв. мәгъ.* Эш яки хәлнең бик каты, көчле, төпле, ныклы булуын күрсәтә. *Гаязның корылыгы Зояны тагын ныграк каушатты.* М. Әмир.

◇ **Нык тору** — 1) бирешмәү. *Кыя ныкторa;* 2) әйткән сүздән, фикердән һ. б. кире кайтмау. *Мирхәйдәр абзый да, Миңниса җиңги дә үзләренең кызыксынуларында нык тордылар.* Ә. Фәйзи.

НЫКЛАП *рәв.* Нык итеп, җитди рәвештә, чынлап, җентекләп, кирәгенчә. *Зиннур, кулына фонарь тотып, бик ныклап тикшереп чыкты.* С. Рафиков. — *Без әле ул турыда сөйләшербез, ныклап сөйләшербез.* Р. Ишморат.

НЫКЛЫ *с. к.* нык 4. *Ныклы адымнар.* □ *Татар опера студиясе уку белән производство эшенең, теория белән ижат эшенең ныклы бәйләнеше нигезенә корылды.* М. Җәлил.

НЫКЛЫК *и.* Нык булу. *Саимәдәге ныклык, бер сайлаган юлдан таш яуса да борылмаучы тәвәккәл холык, тойгы һәм карашларындагы үзгәрмәүчән эзлеклелек бик күпләрдә аңа ихтирам уята.* К. Нәҗми.

НЭП *и.* **1.** Яңа экономик политика. *Партия НЭП нигезендә социалистик төзелешкә яхшырак җитәкчелек итә башлады.* КПСС тарихы.

2. *сөйл.* Яңа экономик политика үткәрелгән чор.

НЭПМАН *и. сөйл.* Нэп чорындагы хосусый предприниматель — сәүдәгәр.

НЮАНС *и.* Берәр нәрсәнең бик нечкә аерымлыклары, үзлекләре, төсмерләре. *Төс нюанслары. Көйнең нюанслары.* □ [*Вәсилә*] *һәрбер очракта диярлек нечкә нюанслар белән сөйләшә, эзлекле логикага бай.* М. Хәсәнов. *Шагыйрь татар теленең халыкчан сүз фондын, мәгънәви һәм психологик байлыгын гына түгел, музыкаль яңгырашындагы нечкә нюансларны, интонация һәм басымнарны да тота, файдалана алды.* Г. Халит.

НЯ'НЯ *и. сөйл.* Больницада санитарка.

НӘ *а., терк. иск. к.* ни. *Нә арба, нә чана вакытта әткәй бурлы бияне җигеп урманга барган иде.* Г. Ибраһимов. *Сөйлимме мин төшемдә, аһ, нә күрдем?* Г. Тукай.

НӘБАТ *и. иск. кит.* Үсемлек. *Төрле-төрле яшел, кызыл нәбатларга Рух кертә нурлы кояш, балкып чыгып.* М. Гафури.

НӘГЪЛӘТ *и. сөйл. к.* ләгънәт. [*Шәрәфи:*] *Кияү белән араны бозыштырып, әллә нишләп беткән иде, нәгъләт!* Ш. Камал. *Ләкин хәзер, гөнаһ шомлыгына каршы, котырып уңган нәгъләт бәрәңгене казымыйча булмый.* А. Расих.

НӘГЪМӘ *и. иск.* Көй, җыр, моң. *Бакчаның кайсыдыр почмагында былбылларның да моңлы нәгъмәләре ишетелә иде.* Ш. Камал.

НӘГЪРӘ *и. иск. кит.* Ачы, каты тавыш; акырыш-бакырыш. *Каты нәгърәсе берлән урманнарны тетрәткән --- Арыслан картайды.* Г. Тукай.

Нәгърә ору — бик каты ачулану, җикеренү. — *Шәһит китсәм дә, мәсәлән, риза, син мәлгунь,*

фаразан, дөньяны аздырдың! — дип, нәгърә орган сыман бер тавыш чыгарды [*хәзрәт*]. Ф. Әмирхан.

НӘГЪРӘЛЕ *с.* Каты, кискен. [*Лирик геройның*] *авазы нәгърәле гөрелте булып яңгырый.* Х. Госман.

НӘГЫЗЬ *с. иск.* Яхшы, гүзәл, әйбәт, шәп. *Бик нәгызь 105 номерлы сәйлүн чәен каты-коты белән сүзсез генә эчтеләр дә тавыш-тынсыз гына йокларга яттылар.* Ә. Фәйзи. [*Шкафчы:*] *Тутасы бик нәгызь нәрсә аныңъ.* Г. Камал.

НӘЗАКӘТ *и.* 1. Нәфислек, матурлык (тышкы кыяфәттә, хәрәкәтләрдә). *Нәфисәнең яулыгы өстеннән башын бәйләгән киң зәңгәр тасмасы йөзенә аеруча бер нәзакәт өсти кебек.* Г. Бәширов.

2. Әдәплелек, нечкәлек (мөгамәләдә һ. б.). *Кибеттән чыккач, Нәркис, нәзакәт белән генә саубуллашып, өйләренә кайтып китте.* М. Мәһдиев.

НӘЗАКӘТЛЕ *с.* 1. Нәфис, матур. *Нәзакәтле адымнар.* □ *Матур кыз, зур ыспайлык белән урындыкка утыргач, егеткә ихтирам күрсәтеп, нәзакәтле кыяфәт белән: — Вакытсыз борчуым өчен гафу итегез! — диде.* К. Тинчурин. || Нечкә. *Музыкаль классиканың иң катлаулы, иң нәзакәтле репертуары да аның өчен һава шикелле үк зарур рух азыгына әйләнде.* Ш. Хөсәенов.

2. Әдәпле, игътибарлы, кечелекле. *Бу — Габдулладан бер-ике яшькә олырак, ыспай киенеп йөри торган нәзакәтле генә егет иде.* Ә. Фәйзи. | *рәв. мәгъ. Дәрәҗәсен белә Зөһрә, нәзакәтле тота үзен.* Г. Латыйп.

НӘЗАКӘТЛЕЛЕК *и.* 1. Нәзакәтле, әдәпле булу.

2. *к.* нәзакәт (1 мәгъ.). *Тышкы пөхтәлеге, интәшләр арасында гаҗәеп бер нәзакәтлелеге, мөлаемлыгы белән Әмирхан ---* [*башкаларның*] *капма-каршысы иде.* Ф. Хөсни.

НӘЗАКӘТЛӘНҮ *ф.* Бик әдәпле, нәзакәтле булып китү яки шундый булып кылану.

НӘЗАРӘТ *и. иск кит.* 1. Күзәтү, карау. *Нәзарәт тәртибендә.* □ *Абзый өйдә булгач, безнең өстәге гадәттән тыш авыр булган нәзарәт тә бераз йомшый төште.* М. Гафури.

2. Идарә. *Хәзер, „Рус Ведомосте“ газетасының хәбәренә күрә, мәгариф нәзарәтендә* [*университетлар*] *өчен яңа устав эшләнеп тәмам була икән.* Ф. Әмирхан.

НӘЗАФӘТ *и. иск. кит.* Чисталык, пакьлек, гигиена. *Кирәк мунча, кирәк пакьлек, нәзафәт.*‘ Н. Исәнбәт.

НӘЗАФӘТЛЕК *и. иск. кит.* Чисталык, пакьлек, пөхтәлек.

НӘЗБЕРЕК *с. сөйл.* Аш-суны бик сайлаучан, талымчан.

НӘЗБЕРЕКЛЕК *и. сөйл.* Нәзберек булу.

НӘЗБЕРЕКЛӘНҮ *ф. сөйл.* Аш-суны бик сайлаучан, талымчан булып китү.

НӘЗЕГӘЮ *ф.* 1. Нечкәрү; юкару. *Пычак уртадан нәзегәйгән.*

2. Ябыгу, чандырлану. *Соңгы вакытта ул бик нәзегәеп китте.*

НӘЗЕК *с. сөйл. к.* нечкә. *Менә Гафифә — унберуникe яшьләрендә нәзек, гүзәл, сөйкемле бер кызчык.* Ш. Камал. *Су буенда таллар нәзек, Яфраклары бал гына.* Ә. Ерикәй. *Моржадан нәзек кенә булып сузылган төтен күк караңгылыгына кереп югала.* Ф. Кәрим.

НӘЗЕР *и. дини.* Үз өстенә үзе алган эш, шартлы вәгъдә. [*Гөлбану:*] *Нәзерем булсын, җиде атнада җиде газизләр рухына җиде ясин укып багышлармын.* Г. Камал. *Әмма әйтеп куйган нәзерем бар: исән-сау илгә кайтсам, әнкәйнең түшәк-ястыкларына чумып, бер өч тәүлек тоташтан мәртәкә киткәндәй йоклаячакмын, насыйп булса.* Ә. Еники.

Нәзер бирү — хорафат-йола буенча: вәгъдә ителгән нәрсәне бирү. **Нәзер әйтү (итү)** — берәр эш башкару алдыннан, ул эш уңышлы барып чыкса, кемгә дә булса берәр нәрсә бирергә яки берәр йөкләмә үтәргә үз күнелеңнән үзең вәгъдә бирү. — *Терелсәм, бурлы биямне* [*Хафизга*] *дога кылдырырмын дип нәзер әйткән идем.* Г. Ибраһимов.

НӘЗЕР-НИЯЗ *җый. и. иск. кит.* Һәртөрле нәзер. *Зәкатеннән дә, нәзер-ниязларыннан да һичбер вакыт коры калдырмый.* Г. Камал.

НӘКЪ *кис.* 1. Вакыт һәм урынны белдергән сүзләрдән алда килеп, төп-төгәл дигән мәгънәне аңлата. *Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл, Кырлай диләр.* Г. Тукай. *Нәкъ биш ел тулды минем шул эшемә.* М. Гафури. *Д күктә, нәкъ баш очында, бик дәртле итеп тургай сайрый иде.* Г. Гобәй.

2. Исем, алмашлык һәм рәвешләр янында килеп, охшатуны тагын да көчәйтә төшә. *Соловьев үзе дә, нәкъ өйдәгечә, якасын ычкындырып җибәргән килеш утыра.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Нәкъ өстенә басу** — төп-төгәл әйтү яки күрсәтү. [*Мотый:*] *Ни булды, сеңелем? Нәкъ өстенә генә басты мәллә малаең?* [*Хәсәннең җилкәсенә суга.*] *Син, усал малай, нигә кешегә туры әйтеп, ярасына тоз саласың? Ә?* М. Фәйзи.

НӘКЫС *и. иск. кит.* Кимлек, җитешмәүчелек.

НӘКЫШ *и.* 1. Агач, сөяк кебек нәрсәләргә кисеп, уеп, сырлап яки чокып ясалган бизәк, орнамент. *Бу өйгә беренче тапкыр аяк баскан кеше --- яшел, зәңгәр һәм башка шуның кебек төсләрдән гыйбарәт нәкышләренә игътибар итмичә калмый торгандыр дип уйлыйм.* А. Шамов.

2. Чигү, чигеш. *Җиңги чәнчә, мин тартам, мин дә нәкыш беләмен.* Мәкаль.

НӘКЫШЛӘНҮ *ф. к.* нәкышләү. *Сарае зур, нәкышләнгән, энҗеләнгән, Кискен нурлар сибелеп тора энҗеләрдән.* Һ. Такташ.

НӘКЫШЛӘҮ *ф.* Уеп, сырлап яки чокып бизәкләр төшерү, бизәү. *Нәкышләп кылыч кою.*

НӘКӘС *с. иск.* Ачулану, сүгү сүзе: яраксыз, ялкау, иренчәк. [*Газиз*] *ике сүзнең берендә шәкертләрне, абзасы төсле, „нәкәсләр“ дип сүгүме дисең, һәммә этлекне эшли.* Ш. Камал.

НӘЛӘТ *и. диал. к.* ләгънәт. *Хәдичә түти --- күз яше белән нәләт укый-укый еларга тотынды.* Г. Бәширов.—*Мең нәләтләр яуса иде сезгә!* Ф. Бурнаш.

◇ **Нәләт камыты** — *к.* ләгънәт камыты. *Дүрт ай астерхан белән Мәкәржә арасында, нәләт камыты киеп, кычкыра-кычкыра көймә тарттым.* Г. Ибраһимов.

НӘЛӘТЛӘҮ *ф. к.* ләгънәт уку. *Син дошманны тыныч яткырмадың, Нәләтләп һәм ачып этлеген.* М. Җәлил.

НӘМУНӘ *и. иск. кит.* Үрнәк, өлге. *Гомумән* [*Зыяны*] *яраталар, аңа якынлык хис итәләр, аны һәр җирдә нәмунә булырлык бер егет кебек тоталар.* Г. Ибраһимов.

НӘНИ *с.* 1. Кечкенә. *Рәфгать тә аптырап калмады, үзенең нәни кулын командирның зур кулына куйды.* А. Әхмәт. *Иртә белән* [*Хәйдәр*] *янына нәни капчыкларын асып егерме җиде бала килде.* Г. Бәширов.

2. *и. мәгъ.* Кечкенә бала. *Нәни, ябык куллары белән Гөлсем апаның ягымлы елмайган ирен кырыйларын тотып, ашарга сорады.* Г. Гобәй. *Зур өйнең ишекләреннән, шау-гөр килеп, нәниләр йөгерешеп чыгалар.* Г. Минский.

3. *рәв. мәгъ. диал.* Аз. *Нәни генә калды.*

НӘНӘ *и. диал.* **1.** Әби, ата-ананың анасы.

2. Әни.

3. *тарт. форм.* **нәнәм.** Үзеннән кечеләргә иркәләп әйтү сүзе. — *Гомәр, кер әле, нәнәм, безгә курай уйна!* Ф. Әмирхан.

НӘП-НӘЗӘК *с.* Бик нәзек, артык нәзек. *Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе.* Г. Тукай.

НӘРКИЗ *и. бот.* Хуш исле, ак яки сары чәчәкле, суганчалы декоратив үсемлек; *русчасы:* нарцисс. *Түтәлне тутырып үсә җиләкләр, Нәркиз, миләүшә, сөмбел һәм мәкләр.* М. Җәлил. *Эссе көн сүрелеп бара. --- Терраса алдындагы георгиннар, нәркизләр, резедалар да --- ачылыбрак киткәннәр.* Ә. Еники.

НӘРКӘС *и. бот. к.* нәркиз. *Нәркәс — күпьеллык, суганчалы, чәчәкне иртә ата торган, кышка чыдам үсемлек.* Йорт эшләре.

НӘ'РСӘ *сор. а.* **1.** Нинди дә булса предмет, күренеш, процесс һ. б. турында сорауны белдерә. [*Сылу:*] *Ул билеңдәге кечкенә капчыкта нәрсә, бабай?* М. Фәйзи. || Кеше яки әйбернең эше, хәрәкәте, торышының сәбәбен сораганда кулланыла. — *Син нәрсә --- кайгыга баттың?* Ш. Усманов. — *Нәрсә болай моңаеп утырасың?* Ә. Айдар. || Инкярны белдергән риторик җөмләләрдә „башка бернәрсә дә түгел“ дигән мәгънәне аңлата. *Ана — Бөек исем. Нәрсә җитә ана булуга! Хатыннарның бөтен матурлыгы, Бөтен күрке ана булуда.* Һ. Такташ.

2. Әйтелгән сүзне яңадан кабатларга кирәклеген белдергәндә һәм гомуми сорауны аңлатканда сүз-җөмлә булып кулланыла. — *Нәрсә? — диде Һарун,* [*Мансурның*] *ни турыда сораганын аңлап җитмичә.* Н. Фәттах. || Сорау кисәкчәсе буларак, сорау җөмләнең башында сорау интонациясен тагын да куәтләү, көчәйтү өчен кулланыла. — *Нәрсә, син хәзер әллә шул тиреченең Вәли җырларын җырларга керештеңме?* Г. Ибраһимов. — *Нәрсә, берәр кирәкле сүзең бармы әллә, Миңзифа?* Ш. Камал.

3. Риторик сорау һәм юклык формасындагы өндәү җөмләләрдә „бик күп, бернәрсә дә калдырмыйча, барысын да“ кебек мәгънәләрне белдерә. *Нәрсә турында гына сөйләшмәделәр алар ул кичтә!* Азат хатын.

4. „Менә“ күрсәтү алмашлыгы янында: басым ясап күрсәтү яки санап китү алдыннан (яисә аңардан соң) гомумиләштерүче функциясендә кулланыла. — *Менә нәрсә, Фәхрия: мин баягынак әнкәң белән сөйләштем.* Ш. Камал. — *Ну, Җамалетдин Гыйлажәтдинович, менә нәрсә, унбиш процент бирерсез.* Г. Камал.

НӘРСӘ' *и.* **1.** Әйбер, предмет. — *Өй котлап менә мин дә сиңа хәлдә барынча әз-мәз нәрсә китергән булдым.* Г. Ибраһимов. *Чатыр янында сандал һәм вак-төяк нәрсәләр ята.* М. Фәйзи. || Әдәбият, сәнгать, фән әсәре, китап һ. б. турында гомумиләштереп әйткәндә кулланыла. *Кайчандыр укылган вактөяк шигырьләрдән, сәнгать һәм идея ягыннан түбән торган берничә нәрсәдән башка әйбер искә төшми.* Һ. Такташ. [*Салих*] *әллә нинди гыйбрәтле нәрсәләр язган.* Г. Ибраһимов. || Чынбарлык күренеше, факт; нинди дә булса эшчәнлекнең чагылышы, нәтиҗәсе; эш. [*Рәхимова*] *аз гына шелтәләгән кыяфәт белән, үтә җиткереп, бик гыйбрәтле нәрсәләр турында сөйләп китте.* М. Хәсәнов. *Мин алардан соңгы разведканың нәрсә белән беткәнен сораштым.* Ә. Айдар. | *хәб. функ. Кеше күңеле — гажәп нәрсә!* Ф. Хөсни. [*Далада*] *дым — бик кадерле нәрсә.* Н. Фәттах.

2. Кеше, зат. *Ярый әле, килене бик зирәк нәрсә, Хәдичә түти искәнә башлауга, ялт итеп торды да, --- минут эчендә сүндереп тә куйды.* Г. Бәширов. || Берәр кеше яки әйбер турында бик үк яратмыйча, ошатып бетермичә әйткәндә кулланыла. [*Җәмиләнең*] *ире — бер юньсез нәрсә шунда.* М. Гафури. — *Күргән кешеләр әйтәләр, ди: Фәтхетдин бу нәрсәне алып кайткан кайтуын, аның ураккa биле бөгелә микән соң дип, ди.* М. Гали. || *эвф.* Берәр кеше яки әйберне үз исеме белән атамыйча, читләтеп әйткәндә кулланыла. [*Сәфәр:*] *Теге нәрсә башны бик томалап ташлаган иде, каһәр!* Ә. Фәйзи.

3. *бәйл. функ.* Иярченле кушма җөмләдә баш җөмләгә иярчен җөмләне бәйләүче мөнәсәбәтле сүз ролендә килә. *Оясында нәрсә күрсә, очканында шул була.* Әйтем.

НӘ'РСӘГӘ *а.* Эш яки хәлнең сәбәбен ачыкларга теләп сораганда кулланыла. — *Нәрсәгә җәберсендең, күз нурым?* Ш. Камал. || Эш яки хәлнең максатын ачыклап сораганда кулланыла. — *Нәрсәгә кирәк булды икән бу кан?* Ә. Айдар.

НӘРСӘ'ДЕР *а.* Билгесез предмет яки күренеш. *Газинур капитан Бушуев землянкасына килеп кергәндә, рота командиры нәрсәдер укып утыра иде.* Г. Әпсәләмов. *Закир кулларын хәрәкәтләндерә, нәрсәдер сөйли.* Ф. Әмирхан.

НӘ'РСӘДӘН *а.* Сәбәпне сорау өчен кулланыла. *Тавыш нәрсәдән чыкты икән? Нәрсәдән алай булды икән?*

НӘРСӘДӘ'НДЕР *а.* Эш яки хәлнең сәбәбе билгесез булуны белдерә. *Нәрсәдәндер шунда мин курыктым.* М. Гафури. *Көмеш шикелле ачык тавышлы кызлар нәрсәдәндер чыркылдашып көләләр.* А. Шамов.

НӘРСӘ'-КАРА *җыйм. и.* Һәртөрле әйбер, нәрсә. *Дөнья чыптачы Гәрәйнең яшь хатыны калдык-постык нәрсә-караның барысын да --- үз туганнарына озатып тора дип сөйлиләр.* М. Галәү.

НӘРӘТӘ *и.* Талчыбыктан авызы бүрәнкә сыман итеп, тар озын кәрзин формасында үреп эшләнгән балык тоту коралы. [*Локман карт*] *язын-җәен нәрәтә белән балык аулап --- яшәде.* Ә. Еники. *Күлнең бер як читендәрәк балыкчылар --- әрле-бирле йөриләр, кичтән салып калдырган нәрәтәләрен карыйлар.* М. Гафури.

НӘСЕЛ *и.* **1.** Бер бабадан килә торган кешеләр буыны, ыру. *Борынгыны яхшы белүче картлар Акбитнекеләрне ил батыры Моратай нәселеннән килә дип сөйлиләр.* Г. Бәширов. *Авылда --- иң атаклы нәсел булып саналган Габдуллажанның бердәнбер улы Хисами соңгы вакытларда еш кына Миңсылуны телгә ала башлаган дип сөйлиләр.* Г. Минский.

2. Тумышы, чыгышы ягыннан берәр социаль төркемгә караган булуны белдерә. *Эшче нәселе. Дворян нәселе.* □ [*Фатыйма абыстай*] *кала кызы; мирза нәселеннән.* Г. Ибраһимов. *Нәсел һәм кан ягыннан аларның Хәмзә байга һичбер мөнәсәбәтләре юк.* М. Гали. *Килен, шәһәрдән, затлы нәселдән булуына карамастан, --- йортка тиз ияләште.* М. Мәһдиев.

3. Гомуми эш белән, интереслар белән бәйләнгән бер тирә-яшьтәге кешеләр, кордашлар; бер буын кешеләре. *Без — тезләнә торган нәсел түгел, Без бәйсезлек өчен кан түктек.* Ә. Ерикәй. *Һәр көрәшнең Алгы сафына килеп баса ул: Күкрәгенә Ике орден таккан Ленин нәселе — данлы комсомол.* Ф. Кәрим.

4. Авыл хуҗалыгы яки кайбер башка хайваннарның буыннан буынга күчә торган билгеле бер сыйфатларга һәм үзенчәлекләргә ия булган токымы. [*Нургали*] *әле беркем дә телгә алмаган өр-яңа нәрсәне — терлекләрнең нәселләрен яхшырту мәсьәләсен кузгатты.* Ә. Еники.

Нәсел агачы — *к.* шәҗәрә. **Нәсел айгыры (үгезе)** — нәселле, яхшы токымнан булган, токымны дәвам

иттерергә калдырылган айгыр (үгез). *Иң ахырда җыелыш карар чыгарды: — Сыерлар абзарына ремонт ясарга, --- яхшы нәсел үгезе алырга.* Ә. Айдар. **Нәселгә калдыру** — йорт хайваннарының, кош-кортның иң яхшысын сайлап алып, үрчемгә калдыру. [*Әтисенең*] *һәр елны нәселгә калдырган бер әтәчен күршесенең усал әтәче талап аптыраткан.* Г. Әпсәләмов.

НӘСЕЛДӘНЛЕК *и. биол.* Организмның эчке яки тышкы төзелешендәге һәм шулай ук тормыш эшчәнлегендәге охшашлыкның буыннан буынга саклануы һәм күчүе. *Гомуми биология организмнарның --- матдәләр алмашын, тынычсызланучанлыкны, --- үрчү, үзгәрүчәнлек, нәселдәнлек һәм тарихи үсеш законнарын өйрәнә.* Биология.

НӘСЕЛДӘШ *и.* Бер нәселдән булган, бер нәселгә караган кеше. *Без Галимовлар белән нәселдәш.* Каз. утл. || Бер халык, бер милләт кешесе. || Бер төр, төрдәш (хайваннар һәм үсемлекләр турында). *Культуралы үсемлекләрнең кайбер төрләре үзләренең кыргый нәселдәшләреннән аз аерылалар.* Биология.

НӘСЕЛДӘШЛЕК *и.* Бер нәселдән булу.

НӘСЕЛЛЕ *с.* Яхшы токымнан булган. *Колхозның нәселле ак үгезе болын уртасындагы үр өстенә менеп баскан да ак мәрмәрдән киселгән һәйкәл сыман кузгалмыйча тора.* Г. Әпсәләмов. [*Исхак*] *совхозга нәселле бозаулар алырга киткән дә, әле һаман кайтмаган.* А. Расих. || Яхшы нәселдән, гаиләдән булган. *Шибайдан яучы килеп, мәһәр акчасын алгач та, карт, башкалар кебек, кияүне кышкы челләдә салкын келәткә ябарга ошатмады, нәселле, затлы кешенең баласы бит дип, --- Хәмиттән калган өйне тиз генә төзәттеләр.* Г. Ибраһимов.

НӘСЕЛЛЕЛЕК *и.* Нәселле булу сыйфаты. *Сыерларның нәселлелеген яхшырту.*

НӘСЕЛ-НӘСЕЛДӘН *рәв.* Ата-бабадан. *Шәүлихан— нәсел-нәселдән килгән бай.* Т. Гыйззәт.

НӘСЕЛ-НӘСӘП *җый. и.* Туганнар, туган-тумача, кардәшләр. *Үз белдеге белән генә өйләнеп, күрмәгән-белмәгән, нәсел-нәсәбе таныш булмаган әллә нинди бер нечкә сыйракны җитәкләп кайтса да берни эшләр хәлең юк... Г. Бәширов.*

НӘСЕЛ-НӘСӘПЛЕ *с.* Туганнары булган, туганнары күп булган. *Нәсел-нәсәпле, укымышлы кыз, күрер күзгә бик чибәр.* Ф. Әмирхан.

НӘСЕЛ-ЫРУ *җый. и. к.* нәсел-нәсәп. — [*Галимә*] *бөтен нәсел-ыруга оят китерде, — диде әни.* М. Гафури.

НӘСЕР *и. әд.* Эмоциональлеге, ритмлылыгы белән шигъри сөйләмгә якын торган, кечкенә күләмле һәм лирик-патетик характердагы чәчмә-прозаик әсәр. [*Г. Кутуй*] *халыкның --- ихтыяры көчен, мораль һәм рухи бөеклеген бик күп очеркларда, шигырьләрдә, ялкынлы публицистик мәкаләләрендә һәм нәсерләрендә чагылдырды.* Г. Кашшаф. || Проза. *Кави шигырь белән дә, нәсер белән дә яза.* Г. Нигъмәти. *Хәзер хәзрәтнең нәсер белән язган әсәренә килик.* Ф. Әмирхан.

НӘСЫЙХӘТ *и.* Үгет, яхшы киңәш; акыл бирү, яхшылыкка өндәү, вәгазьләү. *Нәсыйхәтне тыңламасаң, Күп сөйләсәң, Зарарын үзең күрерсең бигрәк.* М. Гафури. *Әткәй, синең нәсыйхәтеңне тотып, --- үзебезнең районга агроном булып эшкә кайтам.* Г. Минский.

Нәсыйхәт бирү — киңәш бирү, үгетләү, акыл бирү, яхшылыкка өндәү, вәгазьләү. *Нәсыйхәт бирсәң, аулакта бир.* Мәкаль.

НӘСЫЙХӘТЛЕ *с. иск.* Киңәшле, яхшылыкка өнди торган, вәгазьли торган.

НӘСЫЙХӘТЛӘҮ *ф. иск. к.* нәсыйхәт бирү.

НӘСЫЙХӘТЧЕ *и. иск.* Үгетләүче, яхшы киңәш, акыл бирүче, вәгазьләүче.

НӘТИҖӘ *и.* 1. Нинди дә булса эш, күренешнең яки нәрсәнең дә булса үсешенең соңгы йомгагы, күрсәткече. *Имтиханнар нәтиҗәсе. Тикшерүләр нәтиҗәсе.* □ *Газинур кыска итеп разведканың нәтиҗәсе турында сөйләде.* Г. Әпсәләмов. *Большевиклар үз эшләренең нәтиҗәсе белән канәгать калдылар.* И. Гази. || Берәр нәрсәнең ахыры, соңы. *Сөйләшүләр нәтиҗәсендә Мостафин үзе дә йорт салдыру мәсьәләсен хәл кылынып беткән шикелле тоя башлый иде.* Ә. Еники.

2. Файда. *Әхмәтнең тиз арада насосны төзәттереп алып кайтуына кешеләр шатландылар һәм түземсезлек белән аңардан нәтиҗә көтә башладылар.* Ш. Камал.

Нәтиҗә ясау (чыгару) — йомгаклау, йомгак ясау. *Агроном, ашыгыч нәтиҗә чыгарасы килмичә, кистереп берни дә әйтмәде.* Г. Бәширов. **Нәтиҗәгә килү**— берәр төрле фикергә килү, нәтиҗә чыгару. *Агыйделнең бу тәңгәленә [коенырга] килүенә карап кына, [кыз] „Кинҗә" исемле кечкенә башкорт авылыннан булырга тиеш, — дигән нәтиҗәгә килдек.* М. Әмир.

НӘТИҖӘДӘ *терк.* Шуның аркасында, шул сәбәпле, шуңа күрә. *Нәтиҗәдә бүген иртән күп кенә кеше уракка чыкмады, кайберләре чыккач кире кайтып китте.* Г. Гобәй. || Ахырда. *Нәтиҗәдә минем горурым җиңелде.* Г. Ибраһимов.

НӘТИҖӘЛЕ *с.* Нәтиҗәсе уңышлы булган; нәтиҗә (1 мәгъ.) белән бетә торган. *Нәтиҗәле фәнни-тикшеренү эшчәнлеге.*

НӘТИҖӘЛЕЛЕК *и.* Нәтиҗәле булу. *Эшнең нәтиҗәлелеге. Дәреснең нәтиҗәлелеге.*

НӘТИҖӘЛӘНҮ *ф. сир.* Тәмамлану, бетү. *Икенче яктан, поездга артык тоткарлык ясау фронттан кайтучы „дезертирларның" кораллы кузгалышлары белән нәтиҗәләнү куркынычы китереп бастырган иде.* Ш. Камал.

НӘТИҖӘСЕНДӘ *бәйл.* Берәр нәрсә аркасында, сәбәпле. *Шигырь бит ул бик күп көч куеп, озак вакытлар эшләү нәтиҗәсендә генә чын сәнгать үрнәге булу дәрәҗәсенә ирешә ала.* Т. Гыйззәт.

НӘФӘСӘТ *и. иск. кит.* Нәфислек, матурлык. *Бу ике шигырьдә нинди ләтафәт, нинди нәфасәт, нинди поэзия!* Г. Тукай. *Бу вакытта миндә нәфасәт белән ләззәтләнүдән башка бернәрсә дә юк иде.* Ф. Әмирхан.

НӘФЕЛ *и. дини* 1. Бүләк.

2. Тиешле булганнан артыгын эшләү. *Байлар нәфел корбаны дип бер сарык чалдылар.* Ә. Фәйзи.

Нәфел намазы — өстәмә намаз. — *Су буена барып тәһарәт яңартыйм да, ике рәкагать нәфел намазы укып, аулактарак дога кылыйм.* М. Фәйзи. *Алар халык чыгып беткәнче нәфел намазлары укып маташалар.* Һ. Такташ. **Нәфел уразасы тоту** — 1) ураза ае беткәч, әйтелгән нәзерне үтәү максатыннан берничә көн ураза тоту; 2) *күч.* ач тору. **Нәфел әйтү** *дини* — берәр эшнең уңышлы чыгуын теләгәндә корбан чалырга, намаз укырга, ураза тотарга сүз, вәгъдә бирү.

НӘФЕС *и.* Нәрсәне дә булса булдырырга көчле омтылыш; күпне өмет итү, комсызлык. *Нәфес дигән азгын нәрсә миндә дә бар, Ирек кенә бир син аңа, йөгәнләмә...* З. Мансур. *Нәфес-шайтан, бик явыз ул, һәр адәмне аздыра.* Ш. Бабич. || Күңел. *Нәфес тартса, кулга керсә, кайсыбыз соң тартына.* М. Гафури. || Көчле теләк. *Әмма инде кунакларның нәфесе бар икән, алар рәхим итеп әчсен, ул каршы түгел.* И. Гази.

◇ **Нәфес сузу** — өметләнү, кызыгу; аз белән канәгатьләнмәү, күпне өмет итү, комсызлык күрсәтү. [*Ханзафаның*] *шул булыр инде, синең кайтуыңны күреп, нәфесен сузып йөри торгандыр.* Т. Гыйззәт. **Нәфес тыю** — тиешсез эштән тыелу, тукталу; аз белән канәгатьләнә белү, күпкә кызыкмау, комсызлык күрсәтмәү. *Нәфесне тыя алсаң — нәфес юаш.* М. Гафури. *Ул, нәфесен тыярга тырышып, кулындагы икмәк белән колбасаны ашыкмый гына капты.* А. Шамов. **Нәфес төшү** — кызыгу. **Нәфескә баш булу** — *к.* нәфес тыю.

НӘФЕСЛЕ *с.* Нәфесен сузучан, күпне өмет итүчән; туймас, комсыз.

НӘФИС *с.* **1.** Гүзәл, матур; зифа, сылу. *Нәфис гәүдә. Нәфис кыз.* □ *Каеннар үзләре шундый нәфис, шундый сылу, --- аларны кочып үбәсе килә.* Г. Әпсәләмов. || Формасы, күләме ягыннан җыйнак, килешле булган. *Аның нәфис кулында сары саквояж урынында кызыл күннән эшләнгән портфель иде.* К. Тинчурин. || *рәв. мәгъ.* Күркәм, мөлаем, ягымлы. *Ак яулык аның --- йөзен тагын да чистарак, нәфисрәк күрсәтә кебек.* Ә. Еники. || Матур, юка һәм затлы (тукыма һ. б.). *Нәфис ефәк. Нәфис мамык шәл.* || Тотып карауга рәхәтлек тудыра торган, йомшак. *Нәфис мамык.* □ *Минем күз алдымда --- моннан сигез ел элек: „Сезнең чәчегез нинди йомшак, нәфис“, — дип килеп танышкан Искәндәр иде.* Г. Кутуй. || Нәзакәтле, матур (хәрәкәтләр, үз-үзеңне тотыш турында). *Сәхнәгә кара фрак кигән, матур сынлы, нәфис хәрәкәтле бер егет чыгып басты.* Г. Бәширов. | *рәв. мәгъ.* [*Михаил*] *--- озын вә матур сынын нәфис бөкрәйтебрәк тора.* Ф. Әмирхан. *Кыз нәфис кенә итеп скрипканы кулына алды.* А. Шамов. || Матур, ягымлы, аһәңле (тавыш турында). *Нечкә, нәфис тавыш белән --- җавап кайтардылар.* Г. Гобәй.

2. Сәнгатьчә эшләнгән, сәнгатькә, сәнгать өлкәсенә караган; чынбарлыкны образлар аша чагылдыра торган. *Нәфис фильм.*

Нәфис сәнгать — рәсем сәнгате, сынлы сәнгать, архитектура һәм музыканың гомуми атамасы. *Чын музыка бит ул — нәфис сәнгатьнең шундый гажәеп, шундый яшерен көчкә ия булган бер төре.* Г. Бәширов. **Нәфис сүз** — әдәби әсәрләрне сәнгатьчә сөйләү. *Эштән буш кичләрендә Хөршидә ханым Наилә --- симфоник концертларга, нәфис сүз кичәләренә гел үзе белән ияртеп йөрергә тырышты.* Б. Камалов.

НӘФИСЛЕК *и.* Нәфис булу. [*Баланың*] *йөзендә әнисендәге нәфислекнең әсәре дә юк иде.* Г. Гобәй.

НӘФИСЛӘНҮ *ф.* Нәфис булып китү, матурлану, ямьле булу. *Мәңге яшел чыршының ылыслары тагы да нәфисләнеп, юкарып китте.* Каз. утл.

НӘФИСЛӘҮ *ф.* Нәфис итү, матурлау. *Дуслык — кешенең күңелен сафландыра, димәк, ул кешенең барлык башка хисләрен нәфисли.* Г. Әпсәләмов.

НӘФРӘТ *и.* Иң көчле дошманлык, иң көчле күрәлмау хисе. *Юк, түзәлмим йөрәк әрнүемә, Ачуыма, нәфрәт утыма.* Ш. Маннур.

Нәфрәт белән (нәфрәт күзе белән) — дошманлык белән, күрәлмаучылык белән. *Нәгыйм аңар бик каты нәфрәт күзе белән карап алды һәм, җавап бирмичә, башын чак кына читкә борып куйды.* Ш. Камал.

НӘФРӘТЛЕ *с.* Нәфрәт белән сугарылган, нәфрәт хисе чагылган. *Картның сөйләгәнен тыңлаганда кай секундларда йөрәгемдәге нәфрәтле үчтән тыным кысылды.* А. Шамов.

НӘФРӘТЛӘНҮ *ф.* Бик көчле нәфрәт кузгалу, бик ныкачу килү. *Аның нәфрәтләнүенең чиге юк иде.* Г. Әпсәләмов.

НӘХҮ *и. иск. лингв.* Синтаксис. *Дәрес гарәпчә нәхүдән бара иде.* М. Гафури.

НӘШАТ *и. иск.* Шатлык, сөенеч, кәефлелек, җанлылык. *Халыкта кичәге нәшат, кичәге җан калмаган иде: бүген тын, басынкы, авыр.* Г. Ибраһимов. *Менә икенче көн Мостафа нәшатсыз, рухсыз, кәефсез йөри.* Ф. Әмирхан.

НӘШЕР: нәшер итү — матбугатта бастырып чыгару. *Бу көннәрдә шул исемле Шәрәф матбагасы тарафыннан нәшер ителгән шигырь мәҗмугасы идарәбезгә килде.* Г. Камал.

НӘШИР *и.* **1.** *иск.* Нәшрият хуҗасы; матбугат әсәрләрен бастырып чыгаручы; *русчасы:* издатель. *Газетаны яптылар, нәшире Сөләйман Шакировны сөргенгә озаттылар.* Г. Минский.

2. *к.* нәшрият.

НӘШРИЯТ *и.* Матбугат әсәрләрен чыгару эше белән шөгыльләнүче учреждение. *Татарстан дәүләт нәшрияты җырлар җыентыгын чыгарды.* М. Җәлил.

НӘШРИЯТЧЫ *и. иск. сөйл.* Нәшриятта эшләүче; нәшрият хезмәткәре.

НӘҮБӘТ *и. к.* чират. *Кыз да үз нәүбәтендә укый белүе белән бераз мактанып алды.* К. Тинчурин.

НӘҮБӘТЛӘШҮ *ф. к.* чиратлашу.

НӘҮБӘТТӘГЕ *с. к.* чираттагы. *Саммер аягүрә басты да комитетның нәүбәттәге утырышын ачык дип белдерде.* А. Расих.

НӘҮГЫ *и. иск. кит.* Төр (4 мәгъ.), сорт. *Бу нәүгы әдәбият — авыздан авызга сөйләнеп, буыннан буынга калып килгән әдәбияттыр.* Г. Тукай. || Төрле. *Һәр нәүгы гүзәл вә лятыйф күбәләкләр --- сахраның гүзәллегене арттырмакта иде.* Ф. Кәрим. [*Хәмидә*] *Һәммә эшләргә чын күз белән карый, --- һәммәсеннән үзенә күрә бер нәүгы ләззәт таба иде.* М. Гафури.

НӘҮМИЗ *с. кит.* Күңелсез, боек. [*Гәрәй*], *хаксызга рәнҗетелгән кешедәй, бик-бик нәүмиз иде.* С. Сабиров. | *рәв. мәгъ. Рәшидә, --- кичерү сорагандай, нәүмиз генә елмаеп, ике кулын да күкрәгенә куеп, халыкка кат-кат башын иде.* Ә. Еники.

Нәүмиз булу — күңелсез булу, күңелсезләнү, күңелсезлеккә бирелү. [*Нәфисә*] *яшь башыннан тол булып, нәүмиз булып яшәмәсен.* Г. Бәширов. **Нәүмиз итү** — күңелне боектыру, күңелне төшерү. [*Сәйфулла:*] *Шулай мине нәүмиз итеп китәр идеңме?* Х. Вахит.

НӘҮМИЗЛЕК *и. кит.* Күңелсезлек, боеклык. *Оныт нәүмизлекне, оныт; Күрәмсең, күктә бар болыт, Явар рәхмәт, явар әле.* Г. Тукай.

НӘҮМИЗЛӘНҮ *ф.* Күңелсезләнү, боегу. *Без --- Фазыл энем белән икәү ни өчен безнең бай булмавыбыз турында уйлап нәүмизләнеп, бер читкә китә торган идек.* Ф. Хөсни. *Мараты яныннан ул сабыйларча нәүмизләнеп кайтып китте.* Г. Гобәй.

НӘҮРӘП *и. диал. к.* баз (2 мәгъ.). [*Зәйтүнә*] *--- сөтне сөзде, чүлмәккә тутырып нәүрәпкә төшерде.* А. Гыйләҗев. *Фатыйманың өендә ашык-пошык әйбер яшерү башланды; барлы-юклы ашамлыкларны нәүрәпкә төшереп куйдылар.* И. Гази.

НӘҮРҮЗ *и.* **1.** *иск. кит.* Иранлыларның иске календаре буенча яңа ел башы көне (төн белән көннең язгы тигезлек көне, 21 нче мартка туры килә). *Нәүширван патша нәүрүз көненда үзләренең гадәтләренчә зыяфәт* [*кунак итү*] *ясады.* К. Насыйри.

2. Иске татар халык календарендә яңа ел бәйрәме (март аена туры килә). | *күч. Быел эшче нәүрүзы, Буржуйның яңа күзе, Ишетелми һич сүзе.* Г. Камал.

3. *и. бот.* Язын һәм көзен төрле төстә күп чәчәк ата торган бакча гөле; *русчасы:* примула. *Хәзер нәүрүз түтәлләрдә зур булып үсте тәмам.* Ә. Ерикәй.

Нәүрүз бәете — нәүрүз бәйрәме көнендә әйтелә торган бәет. *Нәүрүз әйтә: Мин килдем Театрның түренә, Нәүрүз бәете билгеле Иптәшләрнең күбенә.* Г. Камал. **Нәүрүз бәйрәме** — яңа ел бәйрәме. **Нәүрүз гөле** — ботакланмыйча гына үсә, түгәрәк яфрак яра, зәңгәрсу-ал төстәге чәчәк ата торган бүлмә гөле; *русчасы:* примула. [*Ядвига апа*] *кечкенә чүлмәкләрдә чәчәк атып утыр*[*ган*] *нәүрүз гөлләре күтәреп керде.* Б. Камалов.

НӘҖӘСӘТ *и. иск. кит.* Пычраклык, нәҗес, пычрак (әшәке) әйбер, шакшы нәрсә. *Фәкать акча җыю белән ләззәтләнмәк нәҗасәт вә үләксә белән ләззәтләнүче әт кебектер.* К. Насыйри. *Спиртның яна торганына да, ага торганына да нәҗасәт түгәргә фәрман бирелде.* М. Галәү.

НӘҖАТ *и. иск. кит.* Котылу, исән калу, авырлыктан чыгу. [*Мавия:*] *Үземне үзем сатмасам, бу ят ерак шәһәрдә миңа нинди нәҗат бар.* М. Фәйзи. [*Кабил:*] *Анда утлар... Анда утлар. Тик ул утлардан бу төн Мин нәҗат таптым, сөеклем!* Һ. Такташ.

НӘҖЕС *с.* **1.** Шакшы, пычрак. [*Хаҗия:*] *Нәҗес кулларың белән тотма киемнән.* Т. Гыйззәт. *Булмаса әгәр синдә гакыл кыска, Ышанма асылы нәҗес, залим дуска.* М. Гафури.

2. *и. мәгъ.* Ачулану, тиргәү сүзе. [*Бикморза:*] *Кит, нәҗес, якын киләсе булма!* Ф. Бурнаш. [*Закир:*] *Сез нәҗесләрнең шомлыгы аркасында мондый бәхетсезлекләргә очрадым.* Г. Камал.

НӘҖЕСЛЕК *и.* Нәҗес, пычрак булу.

НӘҖЕСЛӘНҮ *ф.* Шакшылану, пычрану.

НӘҖЕСЛӘҮ *ф.* Шакшылау, пычрату.

НӘҖӘГАЙ *и. диал. к.* ажаган. *Кояш баеган вакытларда кояш баешы якларында уйный торган нәҗәгай утларына карагыз.* Г. Галиев.

НӘҺЕР *и. иск. кит.* Елга. *Матур һавалы көндә бу зур Волга нәһерен сәер вә тамаша кылмак күңелләргә сафа вә сөенчелек бирәдер.* Ш. Мөхәммәдев.

НӨКТӘ *и.* Кемгә дә булса күңелдәге үпкә, кер; хәтер калу. *Ата булган кешегә андыйлар өчен генә күңелдә нөктә сакларга ярыймы соң!* Г. Бәширов.

НӨМАЙШ *и. иск. кит.* Тантана. *Зур шәһәргә керде зур шатлык төсе, Яңгырады шатлык, нөмаиш алкышы.* Ш. Бабич.

НӨСХӘ *и.* Данә, экземпляр. *Рус мәктәпләре өчен һәр елны ничәшәр миллион нөсхә китап хәзерләнә.* Ф. Әмирхан.

НӨҖҮМ *и. иск. кит.* Йолдызлар. *Бөтен инсан вә җир күккә, нөҗүмгә Күңел башлый, котырган күк һөҗүмгә.* Г. Тукай.

Нөҗүм гыйлеме — йолдызларны өйрәнә торган фән; астрономия. *Боларның бөтенесен берьюлы гына дөгалисина да үзенең нөҗүм гыйлеме белән башкарып чыга алмас иде.* Ә. Фәйзи.

О

О I Татар алфавитында унбишенче хәреф.

О II *ы.* **1.** Гаҗәпләну, соклану, курку һ. б. ш. кичерешләрне, хисләрне көчле экспрессия белән белдергәндә кулланыла. — *О, син бик шомлы хәбәрләр белән килгәнсең!* Ф. Бурнаш. — *О-о, Газинур! Алгарак уз әле, карыйм, нинди сержант булгансың!* — *диде ул.* Г. Әпсәләмов. || Раслау һәм инкяр итүне белдергән сүзләр янында килеп, аларның мәгънәләрен көчәйтү, куәтләү өчен кулланыла. — *О-о, юк! Ул бу тирәнеке түгел. Синең аны күргәнең юк.* Г. Гобәй. *Ирек өенә чапты... Дәфтәрен әзләргә китте. Д ул дәфтәр — менә, менә! - - - Әллә ертып ташлыйсымы? О, юк. Кызганыч.* Д. Аппакова.

2. Риторик эндәшле җөмләләрдә аның сәнгатьлелеген көчәйтү өчен кулланыла. *О, кайәр төшкән кысынкы тәкәллефләр, нигә сез яшисез дә, нигә Рахилнең яшь йөрәген тураклыйсыз, нигә аның иң саф, иң матур хисләренә ташып чыгарга ирек бирмисез!* А. Шамов.

ОА'ЗИС *и.* Чүлдә, сахрада үсемлеккә бай сулы урын. *Поезд Ташкентның яшел оазисына килеп керде.* Ш. Усманов. — *Мин сезнең менә бу бакчагызны яратып киләм бирегә, Казанның тузан сахралары уртасына утырган оазис бу минем өчен.* Э. Фәйзи.

ОБЕЛИСК *и.* Өскә таба очлаеп менә торган күпкырлы яисә түгәрәк багана формасындагы таш һәйкәл, корылма. *Бакча зур, матур, урта аллеяда Бөек Ватан сугышында һәлак булган батырларга обелиск куелган.* Г. Әпсәләмов. *Дүрт фамилия язылган гранит обелиск безгә „Яшәүнең кадерен белегез!" ди төсле иде.* Б. Камалов.

О'БЕР-Кушма сүзләрдә хезмәт урыны яки хәрби дәрәҗә ягыннан өлкәнлекне белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: **обер-кондуктор, обер-мастер, обер-лейтенант, обер-ефрейтор.**

О'БЕР-ОФИЦЕР *и.* Патша Россиясе һәм кайбер чит ил армияләрендә капитан яки ротмистрга кадәр булган офицерлык дәрәҗәсе; шул дәрәҗәдәге кеше. *Мөхәммәт улы Бикмиев 1813 нче елда Оренбургта гаскәри (обер-офицер) семьясында туган.* Й. Рәмиев.

О'БЕР-ПРОКУРОР *и.* **1.** Революциягә кадәрге Россиядә Сенат департаменты башлыгы.

2. Революциягә кадәрге Россиядә министр хокукында Синод белән җитәкчелек итүче югары дәрәҗәле кеше.

ОБЕРТОН *и. муз., физ.* Тавышка, төп тонга үзгә төсмер, үзгә сыйфат бирә торган өстәмә тон. *Төп тонга обертоннар никадәр күбрәк кушылган булса, тавыш тембры шулкадәр тулырак һәм төрлерәк, ягъни колакка ятышлырак була.* Физика.

ОБЗОР *и.* **1.** Күрү мөмкинлеге, күз күреме белән иңләп алырлык мәйдан. *Хәйбулла кечкенә бер калкулык янында туктады. „Ярар, шунда көтәрмен. Позициясе дә җайлы, обзоры да киң", — диде ул үз-үзенә.* Г. Әпсәләмов.

2. *кит.* Бер темага бәйләнешле вакыйгалар, күренешләр, фактларга кыскача күзәтү. *Балалар әдәбиятына обзор ясау.*

ОБКОМ *и.* Өлкә комитеты. *Обком бюросы. Обком секретаре.*

ОБЛИГА'ЦИЯ *и.* Отыш яки процент төсендә табыш китерә торган кыйммәтле кәгазьләрнең бер төре. *Дәүләт заемы облигацияләре. Облигациягә отыш чыгу.* □ *Банклар акцияләр һәм облигацияләр чыгаруда, кыйммәтле кәгазьләр белән сәүдәдә шактый роль уйныйлар.* Политэкономия.

ОБЛИГА'ЦИЯЛЕ: облигацияле заем — облигация чыгару юлы белән таратыла торган заем.

ОБЛО'МОВЧЫЛЫК *и. кит.* Үтә ихтыярсызлык, эшсезлек һәм ялкаулык хәле; апатия.

ОБМО'ТКА *и.* Балтырга ботинкадан башлап тез астына хәтле урый торган киң тыгыз тасма; урама. *Ул туңудан бөгелмәс булган салкын бармаклары белән сүтелә башлаган обмоткасын яңадан ура́ды.* Г. Бәширов. *Хәтерлисез микән шлемнарны, Алар ничек утка керделәр, Окопларда ертык обмоткадан Дошманнарга каршы йөрделәр.* Н. Баян.

ОБМО'ТКАЛЫ *с.* Обмотка чорналган; обмотка чорнап кия торган. *Итек урынына обмоткалы ботинкалар кия башлагач, дөньяның рәте китте.* Ә. Маликов.

ОБМУНДИРОВА'НИЕ *и.* Формалы кием-салым комплекты. *Мунчадан соң безгә өр-яңа обмундирование бирделәр дә төп казармага күчерделәр.* Р. Төхфәтуллин.

ОБОЗ *и. к.* олау I (3 мәгъ.). *Көзге юллар буйлап - - - ашлык төягән обозлар агылалар.* К. Басыйров. *Обоз ягыннан берничә бөтен икмәк күтәреп килүче Шәмси күренде.* Г. Бәширов.

ОБОЗЧЫ *и. к.* олаучы. *Элеваторларга табан сузылган олы юл буйлап тезелгән кызыл обозчыларның арба тәгәрмәчләре туңган җир өстендә дыңгырдыңгыр килеп тәгәрәделәр.* М. Әмир.

ОБОЙ *и.* Бүлмә стеналарына ябыштыру өчен махсус эшләнгән бизәкле киң кәгазь тасма. *Көрәнсу обой ябыштырылган җыйнак кына бүлмә иде бу.* Г. Ахунов.

ОБОЙЛАУ *ф.* Обой ябыштыру, обойлар белән ябыштырып чыгу. *Секретарь бүлмәсендә күз чагылдырырлык шомартылган паркет идән, тоныk*

кәгазь белән обойланган дивар. Ф. Сәйфи-Казанлы.

ОБО'ЙМА *и.* Мылтык, пистолет яки автоматны берьюлы берничә патрон белән кору өчен магазин коробкасына урнаштырыла торган металл кыстыргыч. [*Солдат*], *ашыкмыйча, гына обоймадан атылган патрон гильзасын чыгарып, - - - алга таба китте.* К. Тинчурин. || Шундый кыстыргычка куелган билгеле бер сандагы патроннар. *Берьюлы бөтен обойманы атып бетерү.*

ОБОЙЧЫ *и.* Обой ябыштыручы, обой ябыштыру остасы.

ОБОРО'НА *и.* **1.** Билгеле бер урында, позициядә нығып, дошманны тоткарлап, һөҗүмен кире кайтарып тору хәле. *Янган авылның уң ягындагы биеклекне алып, өченче батальонның беренче ротасын оборонага куйдык.* Ф. Кәрим. *Һәр патрон санаулы була башлый. Оборонадагыларның хәле кыенлаша.* Э. Касыймов. || *с. мәгъ.* Шундый шартларда алып барыла торган. *Оборона сугышлары.*

2. Сугыш кырында һөҗүмнән саклану өчен кирәкле чаралар, корылмалар системасы. *Дошман оборонасын өзү.* □ *Боерыкта әйтелгән: Идел буенда оборона торгызу өчен, бөтен халыкны аякка бастырырга!* И. Гази. *Разведкага җибәрелгән Газинур отделениесенең бурычы — һөҗүм алдыннан дошман оборонасының характерын ачыклау иде.* Г. Әпсәләмов. || *с. мәгъ.* Оборона максатларына бәйләнешле. *Оборона корылмалары.* □ *Газетада разведканың уңышлы үтүе, шуның нәтиҗәсендә дошманның оборона серләре ачылып, аның тар-мар ителүе турында язылган иде.* Э. Айдар.

3. Дошманның сугыш белән басып керүен кире кагарга, илнең куркынычсызлыгын тәэмин итәргә сәләтле чаралар җыелмасы. *Илнең оборонасын нығыту.* || *с. мәгъ.* Шундый чаралар белән тәэмин итә торган. *Оборона промышленносте.*

ОБОРО'НАЧЫ *и.* Обороначылык тарафдары. *Обороначы меньшевикларга полиция ярдәм итте. Берәр җыелышта катнашучылар кулга алынса, еш кына обороначылар чыгарыла, ә большевиклар каторгага җибәрелә иде.* КПСС тарихы.

ОБОРО'НАЧЫЛЫК *и.* II Интернационалга кергән оппортунистик партияләрнең 1914 — 1918 еллардагы империалистик сугышта, „ватанны саклау“ лозунгысы астына яшеренеп, үз илләренең буржуазиясен яклау, эшчеләр сыйныфы һәм социализм интересларына хыянәт итү политикасы. || *с. мәгъ.* Обороначыларга хас, обороначылыкка бәйләнешле. *Обороначылык тактикасы. Обороначылык позициясенә басу.*

ОБОРОТ *и. к.* әйләнеш (2 — 4 мәгъ). *Елына икеөч йөз мең сумлык оборот кылса да, Әхмәтсафа агайның конторы-фәләне юктыр.* Ш. Мөхәммәдев. *Мидхәт, - - - зуррак оборот көтеп, Спас базарына җибәрелгән җиреннән, өч-дүрт көн йөреп, коры арбага утырып кайтты.* Ф. Хөсни. || *с. мәгъ.* Әйләнештә, файдалануда булган. *Оборот средстволары. Оборот капиталы.*

О'БРАЗ *и.* **1.** Чынбарлык күренешләрен сәнгатьчә гомумиләштереп күз алдына китерү, зиһенгә алу һәм аларны сурәтләү формасы (әдәбиятта, сынлы сәнгатьтә, музыкада һ. б.). *Образлар белән фикерләү.* || Нинди дә булса күренешне икенче бер конкретрак күренеш нигезендә күрсәтмәле итеп сурәтләү; чагыштыру, охшату. „*Тормышка бәйләнмәгән абстракт образлар шигырьне матурламый да, тирән мәгънәле дә итә алмый.* Һ. Такташ. *Хезмәт иясе крестьяны теле, аның фольклорының җанлы образ һәм сурәтләү чаралары - - - Тукай иҗатына уңай йогынты ясадылар.* Г. Нигъмәти. || Язучы, рәссам, артист тарафыннан тудырылган тип, характер. *Ленин образын сәнгатьтә чагылдыру — гаять бөек һәм шуның белән бергә катлаулы бурыч.* М. Җәлил. „*Беренче театр*“ *комедиясендә иң үзәк образлардан берсе — бөтен искелекне, кирелекне, үзсүзлелекне үзендә гәүдәләндергән Хәмзә бай.* М. Гали.

2. Кем яки нәрсә, аның тышкы кыяфәте, формасы турында җанлы күзаллау; кем яки нәрсәнең дә булса хыялда сурәтләнгән күренеше. *Әгәр Нуруллин ул юлларны үтмәгән - - - булса, Рабиганы да очратмаган, аның образы белән күңелен дә бизи алмаган булыр иде.* А. Шамов. *Килеп басты матур образ булып Хыялларның тәүге чынлыгы.* Ш. Мөдәррис.

О'БРАЗЛЫ *с.* Образларга ия булган; образларга бай, сәнгатьле. *Образлы әйтелмәләр. Образлы сөйләм.* □ *Бабасының - - - тирән тойгы һәм образлы картиналар белән сөйләве Габделкаюмга бик ошады.* М. Гали. [*Язучының*] *образлы сүзе бик күпләргә җан азыгы булды, күңелләрне пакьләндерде, гүзәл эшләр башкарырга канатландырды.* А. Расих. || Образларга нигезләнгән. *Сүз һәр очракта бер үк мәгънәгә ия, бер үк максат белән кулланылган һәм „Беренче карлыгач“ авторларының бердәй образлы фикерләүләре турында сөйли.* Р. Харисов.

О'БРАЗЛЫЛЫК *и.* Образлы булу сыйфаты. *Дәрнең теленә шигъри образлылык җитмәү.*

ОБРЕЗ *и.* Көпшәсе кисеп кыскартылган мылтык. *Корткыч кулын суза һәр урынга, һәр кулакның обрез кулында.* Һ. Такташ.

ОБРОК *и.* Алпавытларга крепостной крестьяннар тарафыннан акчалата яки әйберләтә бирелергә тиешле салым — феодаль эксплуатациянең бер формасы. *Крепостной крестьян үз хезмәте белән эшләп тапкан продуктларын яки акчасын баринга бушлай бирергә — оброк түләргә тиеш булган.* СССР тарихы.

ОБРОКЛЫ *с.* **1.** Оброк түләү яки оброк җыю белән бәйләнгән. *Оброклы хезмәт шартлары.* || Оброк түләүче, оброкка эшләүче. *Оброклы крестьяннар.*

2. Оброкка бирү, оброкка эшләтү белән бәйләнгән. *Оброклы хуҗалык кара туфраклы булмаган районнарда өстенлек алган, бу районнарда крепостной халыкны билләү алпавыт өчен җиргә караганда күбрәк табыш китергән.* СССР тарихы.

ОБСЕРВАТО'РИЯ *и.* Астрономик, метеорологик һ. б. ш. күзәтүләр алып бару өчен махсус җиһазландырылган бина; шундый күзәтүләр алып бара торган фәнни учреждение. *Пулково обсерваториясе.*

ОБСТРУКЦИОНИЗМ *и. кит.* Обструкцияләр куллану юлы белән алып барыла торган политик көрәш системасы.

ОБСТРУ'КЦИЯ *и. кит.* (Гадәттә парламентта) утырышларны, җыелышларны, кемнәрнең дә булса чыгышларын сузарга яки өзәргә юнәлтелгән көрәш методы. *Парламент обструкциясе.* || Ачыктан-ачык берәр эшне булдырмаска юнәлтелгән хәрәкәт, чара. *Перов, чыраен сытып, алга табарак иелде. — Сез нәрсә, — диде ул, әкрен-усал итеп, — монда [җыелышта] обструкция ясамакчы буласызмы?* Ә. Еники.

О'БЩИНА, ОБЩИ'НА *и* **1.** Борынгы сыйныфсыз җәмгыятьтә һәм сыйныфлы җәмгыятькә күчү чорында җитештерү средстволарына күмәк милек, бергәләп хезмәт итү һәм тигезләп бүлү белән характерлана һәм тулысынча яки өлешчә мөстәкыйль идарә ителә торган төрле социаль төркем кешеләр берләшмәсе. *Ыруглык общинасы. Семья общинасы. Вак крестьян общиналары.* □ *Борынгы общинада озак вакытлар буена алмашу өчен җирлек булмаган: бөтен продукт шул община әчендә бергәләп табылган һәм кулланылган.*„ Политэкономия. || *с. мәгъ.* Общинага

нигезләнгән. *Борынгы община строеның таркала башлавы.* || *с. мәгъ.* Общинага караган, общинага бәйләнешле. *Община милке. Община хуҗалыгы.*

2. Борынгы чор һәм урта гасырларда, нинди дә булса территориаль берәмлектә (мәсәлән, авылда яки шәһәрдә) мөстәкыйль идарә ителә торган оешма. *Шәһәр общинасы.* □ *Хосусый милек үсү белән ыруглык бәйләнешләре йомшара бара. Ыруглык общинасы урынын авыл общинасы ала башлаган.* Политэкономия.

Общиналар палатасы — Англия парламентында түбән палата.

ОБЩИ'НАЧЫЛЫК *и.* Община хезмәтенә, тормышына тартымлылык. *Общинаны „социализмның яралгысы" дип карап, народниклар аңарда крестьянның „общиначылык рухы" чагылышын күргәннәр.* СССР тарихы.

ОБЪЕ'ЗДЧИК *и.* Берәр зур участокның сакчысы, шул участокны әледән-әле карап йөрүче. — *Фронттан кайткан солдатлар* [*алпавыт*] *урманын кисәргә керешкәннәр, объездчик барып туктатырга теләгәч, мылтыгын алып, кыйнап киткәннәр.* Т. Гыйззәт.

ОБЪЕ'ЗДЧИКЛЫК *и.* Объездчик хезмәте, вазифасы. — *Мине объездчиклыктан алдылар инде.* Ю. Әминов.

ОБЪЕКТ *и.* **1.** *филос.* Кеше аңыннан тыш яши торган тышкы дөнья, материаль чынбарлык. *Кешенең тормышка — субъектның объектка мөнәсәбәтен революцион практика рәвешендә аңласак кына, тарихта шәхеснең ролен дөрес аңлаган булырбыз.* Г. Нигъмәти.

2. Кемнең дә булса эшчәнлеге, игътибары юнәлтелгән күренеш, предмет, зат. *Фәнни тикшерену объекты.* □ *Лирик шигырьдә автор өчен ижат объекты булып кешенең хисе, эчке кичереше тора.* М. Җәлил. *Газетага мәкалә язганда язасы объектны яхшы белү* [*нең*] *- - - хәлиткеч әһәмияте бар.* Г. Минский.

3. Хуҗалык яки оборона өчен зур әһәмияте булган берәр предприятие, төзелеш, аерым участок һ. б. *Төзелеш объектларын карап чыгу.* □ *Ул яңадан биноклен күзләренә китерде,* [*күперне күзәтте*]. *Сакчылар бар. „Шундый әһәмиятле объектны саксыз калдыралармы соң?!"* И. Гази. *Билгеләнгән сугыш объекты бомбага тотылды.* Г. Кашшаф.

4. *лингв.* Тәмамлык. *Төшем юнәлеше процессның логик объект тарафыннан үтәлүен белдерә.* Д. Тумашева.

ОБЪЕКТИВ I *и.* Оптик приборның бер яки берничә линзадан (оптик пыяладан) торган һәм күзәтелә торган әйбергә юнәлдерелгән өлеше. *Фотоаппарат объективы. Телескоп объективы. Бинокль объективы.*

ОБЪЕКТИВ II *с.* **1.** Кеше аңыннан тыш һәм аңардан бәйсез рәвештә яши торган. *Экономик үсешнең объектив законнары.* □ *Объектив идеалистлар да пространство белән вакытның объектив булуын инкяр итәләр, аларны „объектив рух", „объектив идея" продукты дип атыйлар.* М. Абдрахманов. *Революцияне - - - җанлы ижтимагый көчләрнең көрәше дип карарга кирәк. Бу көчләр нинди дә булса бер билгеле объектив шартлар эчендә яшиләр.* Г. Нигъмәти.

2. Чынбарлыкка туры килә торган, ялгышлыкка юл калдырмаган; гадел, риясыз. *Объектив сәбәпләр.* □ *Үзара сөйләшеп кенә кешеләр дөреслекне табалар. - - - Моның өчен кешегә карата да, үзеңә карата да объектив була белергә кирәк.* Ә. Еники. — *Гафу да, мәрхәмәт тә сорамыйм, хөкемнең объектив карашына тапшырылам.* Г. Ибраһимов. || *рәв. мәгъ.* Чынбарлыктагыча, дөрес итеп. [*Хезмәттә*] *татарларның тормыш-көнкүрешенә аеруча хас булган чисталык объектив күрсәтеп үтелгән.* Каз. утл.

Объектив идеализм — барлык яшәешнең асылы ниндидер үтә абстракт аң — „абсолют рух", „дөнья күләм гакыл" дип тануы белән материализмга капмакаршы булган төп идеалистик агымнарның берсе. **Объектив хакыйкать** — кеше аңында, фәндә чынбарлыкның, реаль дөньяның дөрес чагылышы. **Объектив чынбарлык** — тышкы дөнья, табигать, яшәеш. *Объектив чынбарлыкта бер зарури яки очраклы булган нәрсә һаман да шул ук хәлдә калмый.* М. Абдрахманов.

ОБЪЕКТИВЛАШТЫРУ *ф.* **1.** Реаль, объектив яши торган итү. *Сүзләр ярдәмендә фикерне объективлаштыру.*

2. Гомумиләштерү, типиклаштыру. *Чынбарлык күренешләрен объективлаштырып сурәтләү.*

ОБЪЕКТИВЛАШУ *ф.* **1.** Реаль, объектив яши торган хәлгә килү.

2. Гомумиләшү, типиклашу. *„Объективлашкан" образлы әсәрләр Х. Туфан, Д. Давыдов, Г. Хуҗиев, Ш. Галиев, И. Юзеевлар иҗатында да шактый.* Каз. утл.

ОБЪЕКТИВИЗМ *и.* **1.** *к.* объективлык 2. [*Сәнгатьнең*] *юлы—физикадагы кебек үк, объективизм, чөнки һәртөрле метафизика аңа яттыр.* Г. Ибраһимов. *Һади әфәнде, китабының күп җирендә объективизм саклап,* [*арттырып җибәрүләрдән*] *ерак торадыр.* Ф. Әмирхан.

2. Чынбарлыкка сыйнфый ноктадан карап бәя бирүгә турыдан-туры каршы булган, уйдырма объективлыкка, фәндә, сәнгатьтә „партиясезлек"не яклауга нигезләнгән буржуаз идеология.

ОБЪЕКТИВЛЫК *и.* **1.** Объектив II (1 мәгъ.) булу сыйфаты, үзенчәлеге. *Пространство һәм вакытның объективлыгын исбат иткәндә, диалектик материализм кешелек дөньясының тарихи практикасына һәм фән казанышларына таяна.* М. Абдрахманов.

2. Объектив чынбарлыкка туры килүчәнлек, чынлык; гаделлек, риясызлык. *Мәсьәләне хәл итүдә объективлык булмау.*

ОБЪЕКТИВИ'СТ *и.* Объективизм (2 мәгъ.) тарафдары.

ОБЫВА'ТЕЛЬ *и.* Ижтимагый тормыштан читләшкән, тар карашлы, вак, шәхси интереслар белән генә яшәүче кеше. *Тарихи көрәш көннәрендә шаһит булып тик йөрүче обыватель булмыйча, хаклык ягына күчәргә чын күңелдән омтылуы белән мактанды* [*Сөләйман*]. К. Тинчурин.

ОБЫВА'ТЕЛЬЛЕК *и. к.* обывательчелек. *Крепостнойлык тәртипләрен, обывательлекне тәнкыйть итү Гогольне, бик табигый рәвештә, шул заман чынбарлыгын төшенүгә китерә.* Сов. әд.

ОБЫВА'ТЕЛЬЧЕЛЕК *и.* Ижтимагый тормыштан читләшкәнлек, тар карашлылык. *Обывательчелеккә юл куймау.* || *с. мәгъ.* Обывательчелек белән сугарылган. *Ш. Камал үз әсәрләре белән - - - мещанлыкка, обывательчелек идеологияләренә каршы ут ачты.* М. Җәлил.

ОБЫВА'ТЕЛЬЛӘРЧӘ *рәв.* Обывательләргә хас булганча. *Гөлсем апаның асрамага бала алуын аек фикерле күршеләре мактап сөйләделәр. - - - Әлбәттә, арада бу хәлгә обывательләрчә караучылар да аз булмады.* Г. Гобәй.

ОВЧА'РКА *и.* Көтүләрне саклауда, хәрби санитар, чик буе хезмәтләрендә һ. б. файдаланыла торган көчле этләр токымы; шул токымнан булган эт. *Кавказ овчаркасы. Немец овчаркасы.*

ОГНЕМЁТ *и.* Утлы сыеклык сиптерү (ату) өчен кулланыла торган сугыш кораллы; утаткыч. *Фашистлар*

крепостьны утка тоталар, моның өчен огнемётлар кулланалар. Э. Касыймов.

О!ДА *и.* Нинди дә булса әһәмиятле вакыйгага яки берәр атаклы кешегә багышлап, тантаналы, күтәренке тонда язылган шигырь (лирик жанрның бер төре); мәдхия. *Кызыл Армиянең һәм яшьләрнең батырлыгын, җиңү көчен мактаган одаларында шагыйрьнең патриотик горурлыгы үзенең бөтен күркәмлеге белән гәүдәләнде.* Г. Халит.

ОДЕКОЛОН *и.* Хуш исле матдәләрнең (эфир мае һ. б.) спирт катнашмасындагы эремәсе, ислемайның бер төре. *Сөләйман - - - комод өстендә торган кырлы шешәдән чәчләренә одеколон агызды.* К. Тинчурин. *Хәят - - - одеколонга манчылган яулыгы белән маңгаена кунган черкине куып җибәрде.* Ф. Әмирхан.

ОДЕЯЛ *и.* Ябыныр яту өчен махсус тукып эшләнгән япма. *Мамык одеял. Йон одеял.* □ *Ана, улының аякларын сакланып кына одеял белән томалап, төреп, яңадан урынына утырды.* А. Шамов.

ОЕК *и.* Җептән, йоннан (кулдан яисә машина белән) бәйләнгән яки туладан тегелгән озын кунычлы эчке аяк киеме. *Капрон оек. Йон оек. Тула оек. Оек бәйләү.* □ *Киявегез ярата икән үзегезне, Фәриха ипташ,— диде Каюм,— менә нинди матур оеклар алып кайткан.* Ш. Камал.

Оек эчәсе — оек бәйли торган эшә.

ОЕКБАШ *и.* Кыска кунычлы, балтырсыз оек. *Кыр эшләре бераз җиңеләя башлау белән, кызлар, кич утырып, - - - оекбашлар, бияләйләр бәйләргә тотындылар.* Г. Бәширов.

ОЕКТОКЫЧ *и.* Оек будыргыч.

ОЕК-ЧАБАТА *җыйм. и.* Тула яки йон оек белән киелә торган чабата. *Оек-чабатам эштән чыгып пычранган, эченә су тулып, лаштырдап тора.* Г. Ибраһимов. *Безнең Эшче шундый уйлар белән Үзен-үзе көйләп юата, Сәләмәдер ләкин өс-башлары, Аягында оек-чабата.* М. Гафури.

ОЕКЧАН *рәв.* Оек белән генә, оек кына кигән хәлдә. *Без урамнан җырлап узсак, Кызлар чыга оекчан.* Җыр.

ОЕРША *и.* Вак төер (кар, балчык кисәкчекләре һ. б. ш. турында). *Костя - - - замасканы кулына алды да бармагы белән баскалап карады.— Катырак булган шул, оершалары да калган,— диде.* Г. Ахунов.

ОЕТКЫ *и.* 1. Кайнаган сөтне оету, катык хәленә китерү өчен салына торган аз гына катык. *Гөлбану - - - инде суынып килә торган сөткә оеткы салды.* Г. Ибраһимов. *Камырга — чүпрә, катыкка — оеткы.* Мәкаль.

2. *күч.* Кемгә дә булса хас булган гадәт яки холыкның йогынтысы, тәэсире.— *Әйтми калдырганмын икән әле,— диде Халикъ* [*Нәгыймгә карап*].— *Әткәң Шәйхи мәзин - - - ярлыларны талап йөдәтүдән башканы белмидер иде. Синдә дә аның оеткысы бардыр.* Ш. Камал.

3. *күч.* Берәр төрле иҗади эшнең күңелдә, башта туган идеясе, планы. *Күңелендә йөрткән оеткысын ул якын дуслары белән уртаклашып карый. Аны хуплыйлар, әйбәт була бу, уңыш телибез, диләр.* Г. Ахунов.

4. *күч.* Коткы. [*Минһаж:*] *Колхоз идарәсенә каршы бер оеткы барлыгы сизелә.* К. Әмири.

◇ **Оеткы салу** — 1) нәрсәне дә булса башлап җибәрергә әтәреш бирү.— *Бу курайны әтием төсе итеп саклыйм - - - дип, нәкъ сабыйларча көрсенеп җибәрде* [*Исәнбай*]. *Һәм шуның белән озакка сузылган җитди әңгәмәгә оеткы салынды.* М. Шабай; 2) берәр төрле эш башларга идея, фикер бирү.— *Әткәй, хәйләкәр, оеткыны салды да калганын миңа ташлады.* Г. Әпсәләмов; 3) нәрсә дә булса эшләргә котырту, үгетләү.— *Мин* [*Нәҗиягә*] *оеткыны җитәрлек салдым инде. Үзе фабрикада беренче эшче, мин әйтәм, өстәвенә гармоньда да уйный.* Х. Җәмил.

ОЕТКЫЛЫК *и.* Оеткы өчен булган катык.

ОЕТУ I *ф.* Йокы китерү, йокыга талдыру, изрәтү. *Өзлексез бер нәрсәне такылдаган тәгәрмәч тавышларына тирбәлеп бару Камилне оетты, ул татлы йокыга чумганын сизми дә калды.* М. Әмир. || Онытылдыру, үз-үзеңне тоймау хәленә китерү. *Йокының татлы ширбәте бөтен тәнемә таралган да, - - - рәхәт эчендә оетып яткыра.* Г. Бәширов.

ОЕТУ II *ф.* Оеткы салып ою хәленә китерү. *Сөт оету.* □ *Катыгым бик тәмле. Кичә генә оеткан идем.* М. Фәйзи.

ОЕШ *с. гадәттә каб. форм.* Кисәк-кисәк булып оешкан, укмашкан. *Урман эче җылына төшкәч, әле тегеннән, әле моннан оеш-оеш купшак кар кубып төшкәне тонык кына ишетелеп куя.* Ф. Хөсни. *Сабын күбегенә уралган оеш-оеш чәчләр алга ябылган җәймәгә тәгәрәп-тәгәрәп төш*[*әләр*]. Ф. Яруллин.

ОЕШКАНЛЫК *и.* Бердәмлек, бер максатка омтылучанлык.— *Сезгә шуны гына әйтәсем килә: мондый хәлләр, җәмәгать, безнең арада оешканлык җитмәүдән килеп чыга.* Т. Гыйззәт. *Ул көнге сугышта - - - Молчанов дивизионы аеруча зур оешканлык белән хәрәкәт итте.* Каз. утл.

ОЕШМА I *и.* Иҗтимагый оерләшмә яки дәүләт учреждениесе. *Хуҗалык оешмалары. Профсоюз оешмасы. Сәүдә оешмасы.* □ *Мансуров комсомол һәм партия оешмаларында күп еллар эшләде, үз буыны өлешенә туры килгән һәммә политик көрәшләрнең эчендә кайнады.* Г. Бәширов. *Гыймазов белән дгъләм, район үзәге авылында куныр, иртәгесен, колхоз кирәкләрен кайгыртып, төрле оешмалар*[*да*] *йөрделәр.* С. Рафиков.

ОЕШМА II *с.* 1. *бот.* Бер төпкә оешып, укмашып үскән. *Оешма чәчәкләр. Оешма җимешләр.*

2. *лингв.* Ике яки берничә тиңдәш кисәктән торган. *Оешма ия. Оешма хәбәр.*

Оешма тартыклар *лингв.* — составында ике элемент булган кушык тартык авазлар; аффрикатлар (мәсәлән, ц = т + с, ч = т + ш). **Оешма чәчәкләр** *бот.* — чәчәкләре бер төпкә укмашып үсә торган үләнүсемлекләр семьялыгы. **Оешма җөмлә** *лингв.* — составында тиңдәш кисәкләр булган җәенке җөмлә.

ОЕШМАЛЫ *с. бот. к.* катмарлы. *Оешмалы чәчәкләр.*

ОЕШТЫРМА *и. сир.* 1. Төпле, нигезле, тотрыклы булмаган нәрсә. *Хәкимҗан агайларның бәхетләре дә үзләре, эшләре шикелле дорфа иде, нурсыз иде. Чөнки ул чын бәхет түгел иде, болай гына, балчыктан әвәләп, юатыр өчен генә бирелгән бер оештырма иде.* К. Тинчурин.

2. *мат. күпл.* **оештырмалар.** Бирелгән элементлардан күрсәтелгән санда (икешәрләп, өчәрләп һ. б.) төзелгән һәм берсе икенчесеннән элементларының (нинди тәртиптә булуына карамастан) составы белән генә аерылып торган тоташтырмалар. *Оештырмаларның үзлеге. Кабатлаулы оештырмалар.*

ОЕШТЫРУ *ф.* 1. Иҗтимагый характердагы берәр оешма булдыру, төзү, шуңа нигез салу. *Табигать сөючеләр җәмгыяте оештыру. Кичке мәктәп оештыру.* □ *Алеге егет шул тирәдәге крестьяннардан партизан отряды оештырырга җибәрелгән кеше булган икән.* А. Шамов.— *Без бүген җыелышны ячейка оештыру җыелышы итәбез.* Ф. Бурнаш. || *с. мәгъ.* Берәр эшне башлап җибәрүгә, шуңа нигез салуга кагылышлы. *Җыелышны оештыру мәсьәләләреңә багышлау. Оештыру эшләре.*

2. Төрле чаралар белән булдыру, гамәлгә кертү. *Ярдәм фонды оештыру. Кадрлар хәзерләүне оештыру. Социалистик ярыш оештыру.* □ *Якуб җир өчен көрәшне оештырырга берничә кеше сайлап кую турында сүз кузгатты.* И. Гази. *Англия-Америка империалистлары оештырган чех офицерлары фетнәсе, Колчак ак бандалары Бөгелмәне ике тапкыр канга батырдылар.* Г. Әпсәләмов. || Берәр максат белән күмәк рәвештә нәрсә дә булса ясау, үткәрү. *Якшәмбе көн пионерлар, укытучылары җитәкчелегендә, зур хәзерлек белән өмә оештырдылар.* Г. Гобәй. *Эшчеләр, фашистлар төзелешен җимерү өчен, көчле көрәш алып баралар: эш ташлыйлар, фашистларга каршы демонстрацияләр оештыралар.* А. Алиш. || *күч.* Нәрсә дә булса хәстәрләү, әзерләү. *Ул алдагы атна кичне --- иптәшләренә сый оештырырга вәгъдә итте.* Ә. Фәйзи.

3. Туплау, берләштерү; нинди дә булса эшкә, оешмага җәлеп итү. *Ул авылда тырышып колхоз төзегән, Оештырган ярлы-ялчыны.* Һ. Такташ. *Без бергәләп тракторны каршы алу, бу вакыйгага халыкны оештыру планнарын сыздык.* М. Әмир. *Пугачев явының бер есаулы Булат крепостнойларны көрәшкә оештыра.* М. Җәлил.

4. Вак кисәкләрне бергә жыю, өю яки ябыштырып кушу, укмаштыру. *Степан бабай учактагы күмерләрне оештырып куйды.* Э. Касыймов. || Чуалту, киезләндерү. *Чәчне оештыру. Йон оештыру.*

5. *сөйл.* Кисәкләрдән бөтен ясау, берәр әйбер эшләү; төзү. *Шәһәр чите. Калайлардан, фанера кисәкләреннән оештырылган алачык.* А. Әхмәт. — *Кулар кирелэнмәдеме икән, — дип керешсә дә, [Шәңгәрәй карт бураны] бар кадәренчә җыйнак, пөхтә, чибәр генә оештырды.* Г. Ибраһимов.

6. *күч.* Билгеле бер тәртипкә кертү, жайга салу, көйләү. *Үзеңнең вакытыңны оештыру. Эшне яңача оештыру.* □ *Борһан ага эшне шундый итеп оештырды ки, вахта сәгатьләрендә безнең бер генә минутыбыз да бушка узмый.* Р. Төхфәтуллин.

7. *күч.* Тәртипкә салу, тиешле рәвешкә китерү. *—Шакир, малай, минем хәбәрләр, җыйный торгач, бик күбәеп китте. Үзең оештырып язарсың, яме? ---Аның ижеген-ижеккә китереп оештырып утырырга минем вакыт [юк].* Р. Ишморат. || Хәрефләрне, сүзләрне кыенлык белән кушып уку, сөйләү турында. *Ак бүрекле малай хәрефләрне көчкә-көчкә генә оештыра иде.* А. Шамов. || *рәв. мәгъ.* **оештырып.** Кушып, ялгап. *Габделкаюм --- русча-татарча хәрефләрне оештырып укый башлады.* М. Гали.

8. *күч.* Язу, язып хәзерләү, бастыру (мәкалә, рецензия һ. б. ш.). *Илле-алтмыш юллы гына хәбәрне бик тиз оештыра аласына ышанып, [Әхмәт аны] бүгенгә калдырды.* Г. Минский. *Юбилей уңае белән Тел һәм әдәбият институты һәм Язучылар союзы күп кенә темага гыйльми тәнкыйть мәкаләләре оештырдылар.* М. Җәлил.

Оештыру законы *мат.* — тапкырлау законнарының берсе: бирелгән тапкырлашучыларны бер-бер артлы тапкырлап нәтиҗә чыгару.

ОЕШТЫРУЧЫ *и.* Нинди дә булса эшне булдырырга башлап йөрүче кеше. || Оештыру эшләренә сәләтле кеше. *[Мәктәп] директоры — Гариф Туишев дигән кеше. --- Һәйбәт оештыручы.* А. Тимергалин.

ОЕШТЫРУЧЫЛЫК *с.* Нәрсә дә булса оештыруга юнәлтелгән. *Ул монда яңа тормыш төзүче коллективка оештыручылык эшләре буенча --- килгән.* Ш. Камал. || Оештыру эшләрен яхшы башкаруга бәйләнешле. *Оештыручылык сәләте.*

ОЕШТЫРЫЛУ *ф. Төш. юн. к.* оештыру (1, 2, 4, 5 мәгъ). *Нинаять, безнең авылда егерме дүрт хуҗалыкны эченә алган авыл хуҗалыгы артеле оештырылды.* М. Әмир. *Кулаклардан оештырылган бу банда үзенең ерткычлыгын әле һаман дәвам иттерә.* А. Шамов. *Бу бәйләм, хәзерге вакытта үсә торган чәчәкләрнең һәр төрлесеннән оештырылып, килешле төзелгән, матур бәйләнгән иде.* Ф. Әмирхан.

ОЕШТЫРЫЛЫШ *и.* Нәрсәнең дә булса төзелеше, төзелеш яки эшләнеш формасы (гадәттә әдәби әсәрләр турында). *Ул әсәрләр белән „Матур туганда" арасында --- теманың яктыртылышы, вакыйгаларның оештырылышы, образларның бирелеше буенча охшашлык күренми.* Каз. утл. *Строфа һәр шигырьдә ритмик оештырылышның төп өлгесе булып тора.* Х. Госман.

ОЕШУ *ф.* 1. Барлыкка килү, төзелү (берәр иҗтимагый оешма, берләшмә, учреждение, дәүләт турында). *Феодаль дәүләт оешу.* □ *Колхозлар оешкач, сабан туйларын язгы эшләр беткәннән соң уздыру гадәте кереп китте.* Г. Бәширов. *Оеша дигәч тә, бригада алай тиз генә оешмый әле ул.* Р. Төхфәтуллин. || *күч.* Туу, барлыкка килү (фикер, план турында). *Франция революциясенең зур моментларыннан берсе булган Бастилияне алу фикере ул вакыттагы мәшһүр „Дифоа" кафесында оеша.* Г. Гали.

2. Нинди дә булса максат белән берләшү, бергә туплану. *Хезмәт ияләренең алдынгы өлеше, партизан отрядларына оешып, Кызыл Армиягә ярдәмгә чыкты.* Г. Гобәй. — *Шулай, егетләр, оеша алсак, бергә-бергә күп кенә эшләр эшли алырбыз.* Ф. Бурнаш. || *рәв. мәгъ.* **оешып.** Бергәләп, күмәкләшеп; оешкан рәвештә. — *Әгәр сез оешып эшләсәгез, авыл Советын да бөтенләй үз кулыгызга алып эшләр идегез, менә хәзер авыл Советына кулаклар кереп алган.* М. Гали.

3. Бергә ябышу, укмашу, камыр, замаска кебек хәлгә килү (таркау кисәкләр турында). *Әхмәтнең күз төпләренә кара тузан оешкан, яңак һәм муеннары каралҗым соры тузанга буялган иде.* Ш. Камал. || Чуалу, киезләнү (чәч, йон турында). *[Рахмановның] төркем-төркем булып оешкан озын сары чәчләре, үзләренә башка җаннары бар шикелле, өзлексез хәрәкәтләнеп тора.* М. Әмир. || Куерып, оешкан хәлгә килү, кисәк булып укмашу (кайбер сыеклыклар турында). *Маңгаена кара кан оешып кату.* □ *Көз бозлар катып, Оешып ятып, Чишмәкәй шымды, Бар җиһан тынды.* Дәрдмәнд.

4. Кисәкләрдән бөтен хасил булу, ясалу. —*Шәрәф!.. Ярабби, син бит бу! Ертып ташлаган карточка кисәкләреннән оешып алдыма бастыңмы әллә?* М. Фәйзи. *Китаптагы сүзләр берсе артыннан берсе нигәдер кушылмадылар, җөмләләр дә тиз генә оешмадылар.* Г. Галиев. || *күч.* Бер бөтен хәлгә килү, тиешле дәрәҗәдә эшләнү (сәнгать әсәрләре турында). *Оеша башлаган этапта ук конфликт чишелә, ә роман дәвам итә. Автор конфликтны вакларга, бүлгәләргә тотына.* Р. Мостафин. *Бездә театр китапларына да хәзер кытлык килде. Артистлар нәрсә уйнарга белмиләр. Аптырагач, оеша алмаган тәрҗемәләрне сәхнәгә менгерергә мәҗбүр булалар.* Ан.

5. Бер тирәгә тыгызланып җыелу, өелешү, туплану. *Өсләрен дә чишенмичә, җиде-сигезләп малай, бер почмакка оешып, кайсы тезләнеп, кайсы аяк бөкләп кенә утырганнар иде.* М. Гали. *[Болытлар] тәмам бергә оештылар да, калын катлаулар ясап, яварга охшашлы күгелҗем кара төскә керделәр.* Г. Ибраһимов. || *күч. рәв. мәгъ.* **оешып.** Бергәләшеп, бергә җыйналып; бер семья, бер хуҗалык булып. *[Сәлмән килене Зәйтүнәгә:] Бергә-бергә оешып торсак, барыбыз өчен дә җайлырак булыр дигән сүзем иде. Сугыш чагы. Сезнең дә тормышыгыз җиңелдән түгелдер.* Ф. Хөсни.

6. Сиземчәнлеген, хәрәкәтчәнлеген, сыгылмалыгын югалту. *Утыра-утыра аяклар оешу.* □ *Йомшак тәннәр оешып, эшләп каннар саугачтын, Ягез инде уйнарга, Иркен һава суларга.* М. Җәлил. — *Пенсиядә ятып, сөякләр генә оешып китмәгән булса, бүтәненә кайгырган юк.* Ф. Яруллин.

7. *күч. рәв. мәгъ.* **оешып.** Хәрәкәтсез калып, һич кузгалмыйча. *Иртәдән кичкә хәтле, кушеткага сузылып, - - - тәмам бер бушлык вә мәгънәсезлектә оешып ятам.* Ш. Камал.

8. *күч.* Ялгану, бәйләнү, бер-беренә туры килешү. *Сүзләр авыр вә рәсми бардылар, авыр вә салкын булдылар, бер-берсе белән оешмыйча калдылар.* Ф. Әмирхан.

◇ **Оешкан рәвештә (төстә)** — бергәләшеп, күмәкләшеп, киңәшеп. *Оешкан рәвештә, акыл белән эшләргә кирәк.* К. Нәҗми.

ОЕШУЛЫ *с. сир.* 1. Алдан хәзерләнеп оештырылган. *Оешулы һөҗүм ясау.*

2. Берләшкән, оешкан, нинди дә булса оешма составына керә торган. *Ул берәү генә түгел иҫ... Алар оешулы бер группа, һәммәсе моннан качып-таралып китсәләр, әлеге аларга ияргән, аларның димләве буенча өч көннән эш ташларга карар биргән берничә меңле эшчеләр аларның качуларына ничек караячаклар?* Ш. Камал.

ОЕШЫК *с. сир.* 1. Бергә укмашкан, оешкан, чәбәләнгән. *Оешык йон.* □ *Кояш шәүләсе кызарткан оешык болытлар фикергә калган төсле күренә иделәр.* Ш. Камал.

2. *диал. күч.* Тыныч, талгын. *Башня сәгате торып-торып өч мәртәбә сукты... Оешык тынлыкны кузгаткан аның моңлы тавышлары әллә кайларга озаеп бара иделәр...* Ш. Камал.

ОЗАЙТМА *и.* Озынайтылган яки ялганган өлеш. *Буй җеп озайтмасы.*

ОЗАЙТУ *ф.* 1. *сөйл.* Озын иттерү, озынлыкка сузу. *Урам буена озайтып салынган, асты таш, өсте агач, икә катлы, сигез тәрәзәле өй — морза йортыдыр.* З. Һади. || Сузу, кая да булса юнәлтү (кул турында). *Бер кулына шлемын тотып, икенче кулын көнбатышка озайткан ораторның сүзләре һәркемнең миенә урнашкан уйларны, теләкләрне әйтеп бирделәр.* К. Нәҗми.

2. Нәрсәнең дә булса срогын арттыру, дәвамлырак иттерү. *Командировка срогын озайту.* □ *Әгәр болар [итекчеләр] итек эшләү хезмәтләрен озайтсалар, һаман да итекләрне өчәр тәңкәдән генә сатарга туры килә.* Г. Тукай. *Тик бер минут миңа кирәк Озайтырга гомремне.* Ә. Ерикәй. || Озакка сузу, озак дәвам иттерү. *Бәхәс озайтуны кирәкле тапмау.* || *рәв. мәгъ.* **озайтып.** Озын итеп, җентекләп, тәфсилләп. *Озын сөйләүче мөгаллим эшне килешеп бетерү турында озайтып сөйли башлаган иде, без чыгып киттек.* Һ. Такташ. *Лиза - - - бер яшь офицер белән үзе арасында булып үткән вакыйганы бик озайтып, бик чуарлап сөйләде.* Ф. Әмирхан.

3. *сөйл.* Озакка калдыру, озаклату, кичектерү. *Барган җирдән хат язармын, Тиз җавап бир, озайтма.* Җыр.

4. *рәв. мәгъ.* **озайтып.** Озын итеп сузып, яңгыратып (тавыш турында). *Нәгыйм уянганда, авылның төрле ягыннан озайтып-озайтып әтәчләр кычкырган тавышлар ишетелә иде.* Ш. Камал.

ОЗАЙТЫЛУ *ф. Төш. юн. к.* озайту (1 — 3 мәгъ). *Төрле халыклар шигыренең үз үсешендә без әйткән икенче баскычтан өченчесенә күтәрелүе - - - бер карашка бик гади нәрсәдән тора: шигырь юлы озайтыла.* Х. Госман.

Озайтылган көн группасы — дәрестән соң махсус укытучы-тәрбияче күзәтүе астында ял итү, дәреслөр хәзерләү өчен үз теләкләре белән даими рәвештә кичкә кадәр мәктәптә кала торган укучылар төркеме. *[Миңа] я география дәресен бирәчәкләр, я озайтылган көн группасын алачакмын.* А. Гыйләҗев.

ОЗАК *рәв.* 1. Күп, дәвамлы вакыт эчендә. *Озак йөрү. Озак көтү.* □ *Колхоз председателе Мирсәй абзый да, госпитальдә бик озак ятып, хәзер авылга бөтенләйгә кайтты.* Ә. Айдар. *Уң якта туп аткан тавыш ишетелде, ул каядыр ерактагы караңгылык эчендә авыр һәм озак гөрселдәп торды.* Г. Бәширов.

2. Ерак, озын. *Юл озак булсын, үзләрен күбрәк кеше күрсен өчен, [малайлар] военрукны әйләнечтән, олы урамнан алып китәләр.* Г. Гобәй.

3. *сөйл.* Әкрен, ашыкмыйча. *Озак кыймылдау. Озак маташу.* □ *Ни шайтаныма шулкадәр озак казыналар инде? — дип уйлады ул үзенең иптәшләре турында.* И. Гази. *Бик озак кояш батты. Бик әкрен караңгы төште.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Озын, тәфсилләп, җентекләп. *Драма әсәрләрендәге жанрлар буенча озак тукталырга туры килмәде.* М. Җәлил.

5. *с. мәгъ.* Саны, дәвамлылыгы ягыннан күп булган; байтак. *Бер елны шулай җәен һавалар бик корыга китте, бик озак вакытлар бер тамчы да яңгыр төшмәде.* М. Гали. *Озак еллар сугыш илебезнең Тамырларда канын киптерде.* Ф. Бурнаш. || Күп вакыт сорый торган, ерак. *Ераста, камышлы күлдә, озак юллар очып килеп, бүген ач калган кыр үрдәге тынгысыз бакылдый.* Г. Гобәй.

Озак вакытлы — озак вакытка сузылган. *Озак вакытлы аерылышу. Озак вакытлы сәяхәт.* **Озак сроклы** — озак срокка бирелә торган яки бирелгән. *Озак сроклы кредит күбесенчә капиталь төзелешләргә хезмәт күрсәтә.* Политэкономия.

ОЗАККА *рәв.* 1. Озак вакытка. *Көннәрнең озакка утыруын белдереп, иртә-кич җиңел ак томан йөзә.* Г. Әпсәләмов.

2. Ераккa, ерак киткәнче. *Шәкертләр аларны күзләре белән шактый озакка кадәр озатып калдылар.* Ф. Әмирхан.

◇ **Озакка китү** — 1) күп вакытка сузылу, тартылу. *Хафиз бабай белән гәпләшүләр Бара авыр, китә озакка.* Ш. Мөдәррис; 2) озын, зур күләмле булу. *Идел буендагы хәлләрне хәзергә мин сиңа язмыйм, чөнки ул чагында хат бик озакка китәчәк.* Ш. Камал. **Озакка сузу (җибәрү)** — эшне тиз генә эшләп бетермәү, озак дәвам иттерү; билгеләнгән вакыттан шактый кичектерү.

ОЗАККА'ЧА *рәв.* Озак вакытка чаклы, озакка чаклы. *Мондый дәресләр аның хәтерендә бик озаккача сакланып, ул кубызын һичкем тапмаслык җиргә яшереп куя.* Г. Ибраһимов.

ОЗАКЛАМЫЙ *рәв.* Тиздән, якын арада, күп тә үтмичә. *Көз чуарлый кырны, урманнарны, Озакламый карлы кыш килер.* Ә. Ерикәй. — *Сәгать унбер булган, озакламый поездга төшәргә вакыт җитә.* Г. Камал. *Озакламый каты шартлау булды, Җир тетрәтеп күпер ишелде.* М. Җәлил.

ОЗАКЛА'МЫЙЧА *рәв. к.* озакламый. *Озакламыйча зур үзгәрешләр булыр, тиздән куанычлы хәбәрләр ишетелер!* Г. Бәширов. *Озакламыйча, җир тетрәтеп, мәһабәт кычкыртып, паровоз үзе дә станциягә килеп җитте.* Г. Гобәй.

ОЗАКЛАТУ *ф.* Озакка, күпкә сузу.

ОЗАКЛАУ *ф.* 1. Озак маташу, иркенләү, озакка сузу. *Дминә белән Хәятка йокы урыннары бер бүлмәдә хәзерләнгән иде. - - - Туташлар озаклама-*

дылар, яттылар. Ф. Әмирхан. [*Мәкәрҗәгә барырга*] *вакыт күп калмады, җитте. Ниятебез бик озакларга түгел.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Озак килмәү, килмичә яки кайтмыйча озак тору.— *Тукта, нигә озаклады бу Гөлсинә? Әллә кайтып ук киттеме югыйсә?* Р. Ишморат. — *Әйдәгез, кунаклар, әйдәгез, бик озакладыгыз.* Т. Гыйззәт.

3. *рәв. мәгъ.* **озаклап.** Озак итеп, иркенләп, ашыкмыйча. *Бик озаклап һәм төрле мәсьәләләр турысында сөйләшеп, тәмам төнге уникене җиткердек.* Г. Тукай. *Карап тордым озаклап мин Иделгә.* Б. Рәхмәт.

ОЗАКСЫНУ *ф.* Озак дип санау, озак булып тоелу. — *Мине аналарым артыннан күпмедә илтеп җиткерәсең? Гыйфрит аңарга: — Бер көндә, — дигән иде, егет, тагын озаксыныр, тагын* [*пыялага*] *бер сукты.* Әкият. *Эштән кайтышлый кибеткә кереп тә чират җиткәнне көтәргә озаксынганлыктан,* [*Фатыймага*] *бүләк алмыйча чыгуына да күңеле борчылып куйды.* Ш. Камал.

ОЗАН *и. диал. к.* көртлек. *Кооперативтан бер берданка алып, --- көзен озанга киттем.* Ш. Маннур.

ОЗАТКЫЧ *и. этн.* Киндер сукканда буйлык җепләрне җайлап сузу, озату өчен чөйләр кагып эшләнгән махсус стан.

ОЗАТМА *и.* Туку станына корырлык итеп, билгеле бер озынлыкта хәзерләнгән җеп.

ОЗАТУ I *ф.* **1.** Аерылышканда, саубуллашканда китүче белән бераз вакыт бергә бару. *Таң атып, агач башында төн үткәргән кошлар күңелле чөкердәшә башлагач кына, Закир үзенең Разиясен озатып куя.* И. Гази. *Сәйфулла Мәдинәне авылның түбән очына, амбулаториягә хәтле озата китте.* Ә. Еники. || Саубуллашу, хушлашу. *Казанда мине җылы каршы алдылар һәм бик зурлап озаттылар.* М. Җәлил. *Безнең беребез сугышларга китте, Беребез калды озатып, кул болгап.* Ә. Ерикәй. || *күч.* Кемнең дә булса артыннан ияреп барган кебек булу (җансыз әйберләр турында). *Ай озатты мине клубкача, Ышанычлы дустым шикелле.* Ш. Маннур. *Эйфель манарасы Парижга баручыларны ерактан каршы ала, китүчеләрне еракка чаклы озатып кала.* Г. Гали.

2. Кая да булса илтү, алып бару (юл күрсәтеп, ярдәм итеп, саклап, күзәтеп). *Җиде ай лазаретта яттым. --- Күннән, агачтан, резиннан миңа аяк ясадылар. --- Озатырга бер солдат бирделәр.* Г. Ибраһимов. *Атна-ун көн дигәндә Илдар, мәктәп атын җигеп, әнисен станциягә озатып китте.* Г. Гобәй. || Кая да булса барырга, юлны дәвам иттерергә булышу. *Гәрәй белән Гриша --- кызылгвардеецларны, көймәләргә урнаштырып, аргы якка, Андрей Петрович отряды сугыш алып барган турыга озатып тордылар.* К. Нәҗми. || Кая да булса куу, куып алып бару (маллар турында). *Малларны көтүгә озату.* || *күч.* Зиратка алып барып җирләү (үлгән кеше турында). *Без бүген халык шагыйре Тукайны озатабыз.* Ф. Әмирхан.

3. Берәр төрле максат белән кая да булса җибәрү, барырга мәҗбүр итү. *Себергә сөргенгә озату.* □ *Кәрим авылда булмаган, аны лашманга озаткан булганнар.* Г. Әпсәләмов. || Кызны кияүгә биреп җибәрү турында. [*Карлыгач:*] *Ай ярымнан, туй кылып, мине озатырга телиләр.* Г. Ибраһимов.

4. Китүче кешене, кирәкле нәрсәләр белән тәэмин итеп, булышып яки бу вакыйганы махсус билгеләп, юлга чыгару. *Шәһәргә укырга озату. Солдат хезмәтенә озату.* □ [*Илья:*] *Хәмит дус, мин сине фронтка озаткан идем, инде син озатырга кил.* Р. Ишморат.

5. Китүче, яннан узучы, чыгыш ясаучы кешегә карата нинди дә булса мөнәсәбәт белдерү. *Елмаеп озату. Алкышлар белән озату.* □ *Мотор тавышы тагын һаваны яңгыратты, боз лагере аны кул чабып, биеп, шатланып озатты.* А. Алиш. *Безне әллә нинди --- сүзләр белән озатып калалар, шаярталар.* Г. Ибраһимов.

6. Китүче, ерагаючы кем яки нәрсәне игътибар белән күзәтү, карап калу. *Күзем берлә озаттым: кошчыгым урман таба очты.* Г. Тукай. *Барлык хезмәткәрләр, апалар* [*ана белән баланы*] *күздән югалтканчы озатып калдылар.* Г. Минский.

7. Билгеле бер урынга нәрсә дә булса җибәрү (йөккә, машинага төяп). *Авылга товарлар озату.* □ *Иртәгесе көнне, уннарча йөк белән, Садыйкның яшереп куйган игене шәһәргә озатылды.* Г. Гали. *Ә директор соңгы грузовигын Икмәк белән юлга озата.* М. Җәлил. || *күч.* Яшереп, урлап тиешсез урынга җибәрү, кемгә дә булса бирү.

8. Чыгарып җибәрү (килгән, кергән кешене). *Губернатор, картны көч-хәл белән тыныч ландырып озаткач, үз янына полицмейстерны чакырып алды.* К. Нәҗми. *Бай хатыны булгач, килгән кунакны буш кына озатырга ярамый бит.* Ш. Мөхәммәдев.

9. *күч. сөйл.* Нәрсәнең дә булса тәмамлануын, ахырын билгеләп үтү, шул уңай белән тантаналы кичә, мәҗлес, күңел ачулар оештыру. *Кышны озату. Яңа елны озату.* || Пенсиягә китүче кешене хөрмәтләү мәҗлесе, кичәсе үткәрү. *Пенсиягә озату.*

ОЗАТУ II *ф. махс.* Буйлык җепләрне, туку станына кору өчен, озаткычка сару, чорнау. *Ак укадан җеп озаттым Бер бөртеге калганчы.* Җыр.

ОЗАТУЧЫ I *и.* Китүче кеше белән саубуллашып, озатып баручы, озатып калучы. *Озатучылар, байрак болгап, Җырлар белән озатып калдылар.* Ф. Кәрим. *Хәлим белән Салават, иң арттагы арбага яңа гына чабылып салынган хуш исле үлән өстенә утырып, озатучыларга таба карап баралар.* А. Шамов.

ОЗАТУЧЫ II *и. махс.* Булачак тукыманың җепләрен туку станына корырга хәзерләүче. || Җеп озату станында эшләүче.

ОЗАТЫШУ *ф.* **1.** *Урт. юн. к.* озату (1 — 7 мәгъ). *Мактый бабай белән Мөбарәкша абый да үз атларында* [*безне*] *озатышып бардылар.* Ш. Маннур.

2. Күп кешеләрнең бергәләп озатулары турында. *Безне үстергән аналар, ак сакаллы аталар Озатышып калалар—без китәбез сугышка.* Ш. Мөхәммәдев.

ОЗАЮ *ф.* **1.** *к.* озынаю. *Кояш шактый түбәнәеп, --- күләгәләр озайган иде инде.* М. Әмир. *Көннәр озая, Төннәр кыскара. Бу кайсы вакыт? Я, әйтеп кара?* Г. Тукай. *Бәлки, бу хикәя шуның белән беткән дә булыр иде, бер дә уйламаганнан бераз озаеп китте.* Г. Гали.

2. *күч.* Ерагаю, ераклашу. *Китте егет, кыз озатты Аны фронтка. Озайды аралары.* Ф. Кәрим.

3. *күч. диал. рәв. мәгъ.* **озаеп.** Озак вакыт дәвамында, озаклап. *Яңгыравыклы* [*чаң*] *тавышы моңлы гына озаеп чыңлап китте.* Ш. Камал.

ОЗОКЕРИТ *и. махс.* Балавыз сыман минерал (крем, мазьлар ясау өчен кулланыла); *к.* тау балавызы. *Күп кенә урыннарда нефть чыганаклары белән янәшә асфальтит һәм тау балавызы — озокерит ятмалары табыла.* Нефть тур. хик.

ОЗОН *и.* Көчле оксидлаштыру һәм йогышсызландыру үзлегенә ия булган газ, кислородның бер төре. *Иртәнчәк яңгыр явып үтте. Бөтен тирә-як озон һәм хуш чәчәкләр исе белән тулган иде.* А. Расих.

ОЗОНА'ТОР *и.* Һаваны озонлау өчен кулланыла торган прибор.

ОЗОНЛАУ *ф.* Йогышсызландыру һәм начар һаваны сафландыру өчен озон җибәрү, озон белән эшкәртү. *Һаваны озонлау.*

ОЗОНЛЫ *с.* Составында озон булган. *Чәчәк исләре белән аңкыган озонлы һава аеруча хуш исле.* Ж. Фәйзи.

ОЗЫН *с.* 1. Озынлыгы зур булган; сузынкы; *киресе:* кыска. *Озын урам. Озын күпер. Озын бүрәнә.* □ *Диңгезне каплап алган боз өстендә ак аюлар уйный, симез тюленьнәр шаяра, озын тешле моржлар ял итә.* А. Алиш. *Салыр өчен озын буразналар, Тракторлар сафка тезелә...* Ш. Мөдәррис. || Озынлыгы кирәгеннән артык, таман түгел. *Аклы ситса күлмәгемнең итәге тар, җиңе озын.* Җыр. || *сөйл.* Буйга зур булган (кеше турында). *Әхми үзенең зур, озын сыек гәүдәсен кая куярга аптыраган кебек тора.* Г. Ибраһимов. *Озын казак, дулкынланып, атыннан сикереп төште дә капканы ике куллап дөбердәтә башлады.* Г. Гобәй. || *рәв. мәгъ. каб. форм.* Киң, эреэре **итеп**. *Як-юненә каранып, Хәлим озын-озын атлый.* И. Гази.

2. Озакка сузылган, озак дәвам итә торган. *Кышкы озын кичләрдә бөтен семья ак өйнең олы як сәкесендә җыелып утыра.* М. Гали. *Җырлап үткәргән көннәр, Елап үткәргән төннәр, Бигрәк озын булганнар, Бигрәк әкрен узганнар.* Ш. Маннур. || Озак, дәвамлы. *Тикшеренү эшләренә озын вакыт бирү.* □ *Бу очрашу кыска булса да, Озын булсын безнең танышлык.* Х. Туфан. *Хәмидәгә бу көн бик озын тоелды.* М. Гафури. || *күч.* Күптәннән, озак вакытлардан килгән. *Бу эшнең озын тарихы бар.* Соц. Тат. || Сузынкы, озак яңгырый торган, салмак (тавыш, көй, җыр. һ. б. ш. турында). *Кемдер моңлы итеп баянда озын көй уйный.* Р. Ишморат. *Паровозның озын, моңсу тавышы Хыялымнан мине уята.* Ф. Кәрим.

3. Озак, күп вакыт сорый торган, дәвамлы сроклы. *Без Надя белән ерак диңгезгә таба озын сәфәргә чыгып китәбез.* Р. Төхфәтуллин. *Алар, үзләре озын солдат юлы узган кешеләр булгач, армия тормышы белән гаять кызыксыналар.* Ә. Еники.

4. Зур күләмле. *Озын хикәя.* □ *[Язучының әсәрләрендә] озын, авыр җөмләләр күп очрый.* М. Җәлил. *Миңнурыйның хаты озын иде.* Г. Әпсәләмов.

5. *рәв. мәгъ.* Озак итеп, тәфсилләп, бик җентекләп. *Нәгыйм белән Мәдинә шактый озын сөйләделәр.* Ш. Камал. *Теге шәкерт мөдәрриснең бик озын итеп биргән җавабына тагы бик озын итеп бәхәс әйтте.* Ф. Әмирхан.

6. *бәйл. функ.* Вакытны белдергән кайбер сүзләр янында килеп, „буенча“ мәгънәсен белдерә. *Төн озын йокламау.* □ *Көн озын чайкалып арыган агач башлары инде тынып калганнар иде.* И. Гази.

Озын арба — агач ташу өчен үрәчәсез, төпсез һәм озынча итеп эшләнгән арба. *Ирләр... кичтән әзерләнгән озын арбага ат җигәргә, тырмаларны, сәнәкләрне тутырырга керештеләр.* Г. Ибраһимов.

◊ **Озын аяклы** — тиз таралучан, билгеле булучан (сүз, хәбәр турында). *Ялган хәбәр озын аяклы, ялган сөйләүче озын колаклы.* Н. Исәнбәт. **Озын берлек (акча)** — җиңел юл белән яки хәрәмләшеп табылган зур акча турында. *Кайберәүләр җайлы урын эзли, Озын акча эзли.* Г. Афзал. **Озын гомерле (булу)** — 1) озак яшәү; 2) озакка бару, җитү (мәсәлән, азык-төлек). **Озын гомерле булыр(сың)** — сүз барган кеше үзе килеп кергәндә яки күренгәндә әйтелә. *„Һәй озын гомерле булыр бу Гали“ дип сөенде Гарәфи абзый һәм, урыныннан торып, аларны аягүрә көтә башлады.* Г. Әпсәләмов. **Озын колак** — куян. *— Әй, син, озын колак, хәлең ничек? Син бит бөтен дөньяда иң матур куян булачаксың.* Х. Вахит. **Озын колак аша** — *к.* озын колактан. *Озын колак аша мин Зөһрә турында кайбер бүтән нәрсәләр дә ишеттем.* Н. Фәттах. **Озын колак хәбәре** — ачык билгеле булмаган хәбәр, имеш-мимешләр. *Баштарак колактан колакка сөйләнеп, озын колак хәбәре генә булып йөргән бу сүзләр --- бара-бара дөрескә чыкты.* М. Галәү. **Озын колаклы** — күпне ишетүче, һәрнәрсәдән хәбәрдар булып торучы. *[Арслан:] Озын колаклы булсаң да, минем сүзләрне азрак ялгышрак ишеткәнсең.* Ш. Усманов. **Озын колактан** — кемнән ишеткәнне белгертергә теләмәгәндә әйтелә. *Озын колактан ишетелгән шушы көннең гажәп зур хәбәрен алардан дөресләтү өчен --- дхмәт янына кердем.* Х. Кәрим. **Озын куллы** — 1) юкка-барга сугышучы, кешегә сугарга яратучы; 2) урлашучы, кеше әйберенә тиюче. *[Карчык:] Актык сүзем шул сиңа, --- озын куллы кыз: моннан соң кеше әйберенә тимәскә, алдап сөйләмәскә вәгъдә бирәсеңме?* А. Әхмәт. **Озын сүзнең кыскасы** — җыеп, кыскача гына әйткәндә. *Озын сүзнең кыскасы, әнә шулай эшкә урнашып, мехчы булып киттем.* Ә. Еники. **Озын тел (ле)** — гайбәт сөйләүче, урынлы-урынсыз кирәк-кирәкмәгәнне сөйләп йөрүче кешегә карата әйтелә. — *Озын телләр, кайсы көнләп, кайберләре үч итеп, карчыкның күңел ярасына тагын тоз сибә башладылар.* Г. Бәширов. *Бер яктан, дөнья нужасы җанны кыйнаса, икенче яктан, әнә шундый озын телле --- көнче хатыннарның нахак сүзләре үтерә.* Ф. Хөсни. **Озын торыклы** — 1) озын гәүдәле, гәүдәсе озын (хайван хакында). *Арада бик озын торыклы байтал мине бигрәк тә куркыта.* Ф. Хөсни; 1) озын буйлы (кешегә карата). *Озын торыклы немец, тез астына китереп сукканда, артка чайкалып куйды да аптырашып торган солдатлар арасына авып төште.* И. Гази. **Озын чәч** *иск.* — 1) руслар турында; 2) *кимс.* хатын-кыз турында. **Озынга китү (сузылу)** — *к.* озакка китү. *Әллә ничек сүз озынга китте.* Г. Тукай. *Вакыйга бик озынга сузылган.* М. Җәлил. **Озынга сузу (җибәрү)** — нәрсәне дә булса иркенләп, озак итеп башкару. *Сәхип, аерым көйләрне артык озынга сузмыйча, бер-бер артлы өч-дүрт көй уйнады.* Ш. Камал. *Сүзне озынга җибәрергә курыктым.* М. Гафури.

ОЗЫНАЙТУ *ф. к.* озайту (1, 2, 4 мәгъ.). *Хәлим [атның] артык кыска калдырылган тышавын озынайтып бәйләде дә, гармунын алып, су буена төште.* Г. Гобәй.

ОЗЫНАЮ *ф.* 1. Озынракка әйләнү, ераккарак сузылу. *Төш авышып, күл буендагы өянкеләрнең кара күләгәләре озыная башлаган.* И. Гази. *Авылыбызны яртылай әйләндереп алган Агыйдел озынайды, борылышлары ешайды.* М. Әмир. || Озынчарак форма алу (йөз, яңак, борын турында). *[Галимә апаның], яңагы озынаеп, битләре эчкә бата төште.* М. Гафури. || Озынрак булып үсү. *[Фәхринең] буе бераз озынайган.* Г. Ибраһимов. *Вәсиләнең керфекләре тагын да озыная төшкән төсле.* Ф. Хөсни.

2. Озаккарак сузылу, дәвамлылыгы арту (вакыт турында). *Сүз озынаю.* □ *Көннәр күзгә күренеп озынайды.* Г. Әпсәләмов. *Хәзер безнең очрашу сроклары, ай-һай, ничек озынайды.* Р. Төхфәтуллин.

3. Күләме арту, зураю. *Бу уңышлы мисалларны тагын унга кабатларга була. Мәкалә озынайганга, аларны китереп тормыйбыз.* М. Җәлил.

ОЗЫНАЯК *и. зоол.* 1. Икеканатлылар отрядыннан буынтык-буынтык озын, нечкә мыеклы һәм озын, нечкә аяклы корткыч бөҗәк, озынборыннарның (1 мәгъ.) бер төре; *русчасы: долгоножка.*

2. *диал. к.* озынборын 1. *Без монда чебен-чырак, озынаяк арасында азап чигәбез.* Әкият.

ОЗЫНАЯКЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Озын, нечкә аяклы озынборыннарның (1 мәгъ.) берничә төрен берләштергән семьялыкның атамасы.

ОЗЫНБОРЫН *и.* 1. Нечкә гәүдәле, ике канатлы, озын аяклы, кан эчүче бөҗәк; черки. *Киттән ач калган озынборын - - - чүп утаучыга таба: „Җизни, җизни, күңелем сиңнән бизми!" дип, безелди-безелди кан эчәргә оча.* А. Алиш. *Җил тынып, яфрак шавы басыла барган саен, озынборын күбәйде.* Г. Минский.

2. Коңгызлар семьялыгыннан башының алгы өлеше көпшә сыман булып сузылып торган корткыч бөҗәк; *русчасы:* долгоносик.

ОЗЫНБОРЫНЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Башларының алгы өлеше көпшә сыман булып сузылып торган коңгызлар семьялыгының атамасы.

ОЗЫНБОРЫНЧА *и. зоол.* Чаян-чебеннәр семьялыгыннан корткыч бөҗәк; *русчасы:* комаровка.

ОЗЫНЛЫК *и.* 1. Сызыкның, яссылыкның, җисемнең ике чик нокталары бер-береннән ераклашкан юнәлештә сузылып киткән буе. *Озынлык үлчәүләре. Мәйданның озынлыгын һәм киңлеген үлчәү.* || Нәрсәнең дә булса бер очыннан (ноктасыннан) икенче очына (ноктасына) кадәр булган арасы, озынга сузылыш дәрәҗәсе. *Юлның озынлыгы. Елганың озынлыгы. Әйләнәнең озынлыгы.* □ *Калага кергәч,* [*Хәмидәнең*] *андагы йортларның зурлыкларына, урамнарның озынлыкларына - - - исе китте.* М. Гафури. *Яшүсмер кыз күк чәчәкле җамаяклар белән карандаш озынлыгындагы нечкә очлы таяклар алып керде.* А. Шамов.

2. Вакыт ягыннан булган дәвамлылык; озаклык. *Ш. Камалның татар художество әдәбиятына 30 еллык хезмәте бар. Аның хезмәте, әлбәттә, озынлык белән генә үлчәнә торган түгел, ул катлаулы, тирән һәм данлыклы хезмәт.* Л. Җәләй. *Йокысыз, борчулы төннәрнең, сагышлы көннәрнең озынлыгын һәм авырлыгын кем үлчәгән?* Э. Касыймов.

3. Күләмлелек, күләм ягыннан булган зурлык (язма әйберләр, доклад һ. б. ш. турында). *Кайбер язучылар, әсәрләрендәге - - - артык озынлыклар, кирәкмәгән ваклыклар турында сүз чыкса, бу минем кимчелегем түгел, ә үзенчәлегем дип акланырга тырышалар.* Р. Мостафин.

4. *геогр.* Башлангыч (нульле) меридианнан көнбатышка яки көнчыгышка таба градуслар белән күрсәтелгән ара (җир өслегенең нокталарын билгеләү өчен хезмәт итә). *Бер үк меридианның барлык ноктaлары да бер үк озынлыкта булалар. Иң зур озынлык 180° исәпләнә.* Физ. геогр.

5. *лингв.* Авазның билгеле бер вакыт берәмлеге эчендә булган тирбәнеш саны дәвамлылыгы. *Сузыкларның озынлыгын билгелә.*

ОЗЫНЛЫ-КЫСКАЛЫ *с.* Берсе озын, берсе кыска; төрле озынлыктагы. *Озынлы-кыскалы тавыш чыгарып, маневр ясап йөргән паровозларның тавышлары - - - авыл егетләренең башларын әйләндереп җибәргән кебек булды.* М. Гафури. *Хәзрәтнең озынлы-кыскалы биш чыбыгы бар иде, берсе калмый сынып, мунчалаланып бетте.* Г. Гобәй.

ОЗЫН-ОЗАК *рәв. сөйл.* 1. Озаклап, иркенләп. *Фәсхетдин белән Хәйбулланың озын-озак сөйләшеп утырулары, ике дусның - - - үзләрен бәхетле итеп сизенүләре Гайнижамалга күңелле тәэсир ясаган иде.* Ш. Камал. — *Җәйге мунча гына, ташы да әллә кем түгел, үзең беләсең, бик юка, озын-озак маташсаң, я сүрелеп куяр.* М. Шабай.

2. *с.* Озакка сузылган, ерак. *Бик авыр булса да, бу полкның сугышчылары өчен озын-озак юлларны җәяүләп узу яңалык түгел иде.* Г. Бәширов.

ОЗЫНТОМШЫК *и. зоол. к.* тәлләтәвеч.

ОЗЫНЧА *с.* 1. Буйга сузылган, озынлыгы аркылысыннан беркадәр зуррак булган. *Сайгаклар өстенә кулдан суккан озынча паласлар җәелгән.* Г. Ахунов. *Тукталган җиребезнең көньяк өлешендә озынча һәм тар гына күл.* Ә. Баян.

2. Эллипс сыман сузынкы. *Озынча йөз.* □ *„Кыяр" — Масельская янында дошман урнашкан иң югары биеклекнең солдатлар телендәге исеме иде. Кыяр кебек озынча булганлыгы өчен аңа шул исемне биргәннәр.* Г. Әпсәләмов.

Озынча ми — баш мие кәүсәсенең арка мие белән тоташкан өлеше (сулыш алу, йөрәк-кан тамырларының үзәге урнашкан урын).

ОЗЫНЧАЛЫК *и.* Озынча! булу сыйфаты, үзлеге.

ОЗЫНЧАЛАНУ *ф.* Озынча хәлгә килү, озынаю. [*Кояштагы*] *бу таплар төрле сурәттә вә зурлыкта булалар һәм бәгъзе вакытта түгәрәкләнәләр, бәгъзе вакытта озынчаланалар.* Ф. Әмирхан.

ОЗЫНЧЫК *и. геом. к.* турыпочмаклык.

ОЙ, ОЙ-ОЙ *ы.* 1. Авырту, курку, бик нык борчылу һ. б. ш. хисләрне белдерә. *Илсөяр куркуыннан кинәт кычкырып җибәрде:— Ой! Командир абый!* Г. Гобәй. [*Закир:*] *Ой-ой, әчем! Үләм микән әллә?* Х. Җәмил.

2. Гаҗәпләнү, шатлык, соклану һ. б. ш. хисләрне белдерә. — *Ой! Чиертә, балык чиертә!* Р. Ишморат.

3. Үкенү, шикләнү, күңелсезлек, ризасызлык һ. б. ш. хисләрне белдерә. — *Ой, алдыйсың! Хәзер ни өчен көлеп куйдың? Ялганламый гына әйт әле.* Г. Әпсәләмов. — *Ой, ашыйсым килә!* А. Әхмәт.

ОЙРОТ *и.* Хәзер (1948 елдан) Таулы-Алтай автономияле өлкәсендә яшәүче һәм алтайлылар дип йөртелгән төрки халыкның әлекке атамасы; шул халыкның аерым бер кешесе. *Авылларда татар, кыргыз, ойрот яшьләре арасында, комсомол ячейкалары оештырып, культура-агарту эшләрен җайга салырга кирәк иде.* Г. Камай.

ОЙ-ҺОЙ *ы.* Шикләнү, икеләнү, кисәтү хисләрен белдерә; *к.* ай-һай. — *Сезне аспирантурага алмыйлар. Сез карт. Д ассистент булу - - - беләсезме, ой-һой. - - - Уен түгел ул!* А. Расих.

ОКЕАН *и.* 1. Бөтен Җир шарын чолгап алган сулык. *Октябрьга килдек подваллардан, Штыкларны алга этәреп, Океан дулкыныннан көчле булып, Байракларны күккә күтәреп.* Н. Баян. *Картлар тели аның, кулын кысып, Аркасыннан сыйпап сөяргә, Водолазлар тели океан төбендәге Җиңүләрен аңа сөйләргә.* Ф. Кәрим. || Җир шарын чолгап алган һәм коры җирне аерым материкларга бүлгәләгән дүрт зур сулыкның берсе. *Төньяк Боз океаны. Тын океан.* □ *Чикләреңдә синең өч океан, Дистәләрчә ярсу диңгезең.* Ш. Мөдәррис. || *с. мәгъ.* Океанда йөзү өчен билгеләнгән. *Ярдан шактый ары, су эчендә төрле илләрнең флагларын җилфердәтеп, океан кораблары тупланган.* Р. Мостафин.

2. *күч.* Тиңдәшсез, гаять зур яки күп нәрсә турында. *Ашкынабыз кич тә, көндез дә, Безнең көчләр — океан.* М. Җәлил. *Ибраһимов, Тукай — россиян, Акыллары белән — океан.* М. Хөсәен.

Океан климаты — *к.* диңгез климаты.

ОКЕАНАРИУМ *и.* Диңгез, океан хайваннарын һәм балыкларны тоту һәм аларны күзәтү, фәнни тикшеренү, шулай ук тамаша кылу өчен махсус эшләнгән сулык, бассейн. *Лос-Анджелеста* [*Тын океанның яры буенда*] *иң зур океанариум урнашкан. Океанда*

нинди балык бар — һәммәсен дә күрергә [була. Каз. утл.

ОКЕАНО'ГРАФ *и.* Океанография белгече.

ОКЕАНОГРА'ФИК *с.* Океанографиягә бәйләнешле. *Ясалма иярченнәр ярдәмендә океанографик тикшеренүләр алып бару.*

ОКЕАНОГРА'ФИЯ *и. к.* океанология. *Океанография институты.*

ОКЕАНО'ЛОГ *и.* Океанология белгече.

ОКЕАНОЛО'ГИК *с.* Океанологиягә бәйләнешле. *Океанологик тикшеренүләр.*

ОКЕАНОЛО'ГИЯ *и.* Океаннарны һәм диңгезләрне өйрәнә торган фәннәрнең җыелмасы.

О'КИСЬ *и. хим. к.* оксид. *Терекөмеш окисе. Углерод окисе.*

ОКИСЬЛАШТЫРУ *ф. хим. к.* оксидлаштыру. *Металларны окисьлаштыру.*

ОКИСЬЛАШУ *ф. хим. к.* оксидлашу. *Ацетиленның окисьлашуы.* □ *Глюкозаның бер грамм-молекуласы окисьлашканда 647 000 кечкенә калория энергия аерылып чыга.* Биология.

ОККУПАНТ *и.* Оккупациядә катнашучы кеше; басып алучы. *Фашист, үзе калдырган авылларны яндырып, мондагы халыкны үзе белән куа. Ара-тирә, оккупантлардан качып, безнең якка — үз өйләренә кайтучылар да очрый.* А. Расих. *Юл буендагы усакка кадакланган фанер тактага --- күзем төште. Аңа эре-эре хәрефләр белән: „Немец оккупантларына үлем!" — дип язганнар иде.* А. Шамов.

ОККУПА'ЦИЯ *и.* Берәр дәүләтнең законсыз рәвештә чит территорияне корал көче белән басып алуы.

Оккупациягә әләгү, оккупациядә калу — оккупацияләнгән территориядә калу. *Безнең разведканың бурычы — вакытлыча оккупациядә калган совет гражданнарын --- немецларның ерткычлыкларыннан саклап калу иде.* Э. Айдар.

ОККУПА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Чит территорияне законсыз рәвештә корал көче белән басып алу. *Күрше дәүләтләрнең чиктәш районнарын оккупацияләү.*

ОКЛАД *и. сөйл.* Билгеле бер хезмәткә даими рәвештә түләнә торган эш хакы күләме; эш хакы. *Рәхим физиология кафедрасына ярты оклад белән ассистент булып урнашкач та учхоздагы эшен ташламады.* А. Расих.

ОКОЛО'ТОК *и. иск.* **1.** Революциягәчә Россиядә: шәһәр полиция бүлеге. *Околотокка тотып китерү.*

2. *иск.* Хәрби бүлек каршында дәвалау пункты; лазарет. *Околотокка китүчеләрнең кайберләре терелеп, кайберләре авыру хәлдә, ике-өч көннән соң, землянкага кайттылар.* М. Гали.

ОКОП *и.* Пуля, снарядлар һ. б. тиюдән саклану өчен тирән һәм озын чокыр формасында казып, алдына балчык өеп эшләнгән ныгытма. *Якубның киң аркасы әле бер окоп эчендә, әле икенче окоп эчендә күренде, тавышы әле бер төркемдә, әле икенче төркемдә ишетелеп торды.* И. Гази. *Окоп казып җиргә яшәрендем, Дошман ядрәсеннән үлмим дип.* Э. Ерикәй.

Окоп сугышлары — озак вакытлар бер үк позициядә, окоплар эченнән генә алып барыла торган сугышлар.

ОКОПЛЫ *с.* Окоплар казылган, окоплар белән ермачланган. *Окоплы урыннар.*

ОКОПТАШ *и.* Кем белән дә булса янәшә яки бер окопта булган кеше; сугышта бергә катнашучы. *Бу көнне карт солдат сугыш аша узган авыр юлларын исенә төшерер. Окопташларын сагынып хәтеренә алыр.* Н. Дәүли.

ОКРА'ИНА *и.* Дәүләтнең үзәктән ерак, чик өлкәсе районы. *Россиянең милли окраиналар халкы составыннан 25 миллионга якын кеше капитализмга кадәрге үсеш стадиясендә иде.* Политэкономия.

ОКРО'ШКА *и.* Куаска ит, йомырка, яшелчә турап әзерләнгән салкын аш. — *Су коенып чыгыйк та ашарга барырбыз. „Парус"та телеңне йотарлык окрошкалар була.* Г. Мөхәммәтшин.

О'КРУГ *и.* Дәүләт эчендә политик, хуҗалык, хәрби һ. б. максатлар өчен бүленгән административ территориаль берәмлек. *Сайлау округы. Милли округ. Округ штабының хәрби комитет вәкиле.*

ОКСИД *и. хим.* Нинди дә булса элементның кислород белән кушылмасыннан торган катлаулы химик матдә. *Нигез оксидлары: бакыр оксиды, магний оксиды, тимер оксиды һ. б. Кислота оксидлары: күкерт оксиды, азот оксиды, водород оксиды һ. б.*

ОКСИДЛАУ *ф. тех.* Коррозиядән саклау өчен яки декоратив максатлар белән металлның өсйөзен оксидлаштыру. *Бронзаны оксидлау.*

ОКСИДЛАШТЫРУ *ф. хим.* Оксидлашу хәленә китерү, оксидлашуга дучар итү. *Спиртны оксидлаштыру. Парафинны оксидлаштыру. Металлны оксидлаштыру.* □ *Оксидлар кислород белән гади матдәләрне генә түгел, кайбер катлаулы матдәләрне оксидлаштырганда да табылалар.* Химия.

ОКСИДЛАШУ *ф. хим.* Нинди дә булса элементның, матдәнең кислород белән кушылуын барлыкка китерә торган химик реакция. *Химик элементларның оксидлашу дәрәҗәсе.* □ *Картайган чакта --- катлаулы организмда күзәнәкләр саны азая — организмның авырлыгы, массасы кими. Оксидлашу процессы акрыная.* А. Тимергалин.

ОКТА'ВА *и. муз.* **1.** Гаммада беренче тон белән охшаш яңгырашлы, ләкин югарырак регистрдагы һәм бер үк исем белән атала торган сигезенче тон. [*Планкаларны, телләрне камилләштерү*] *аркасында, татар гармоне октавасы өчен аеруча кулай яңгырашлар сайлап алырга мөмкинлекләр туа.* Каз. утл. || Гамманың бирелгән беренче һәм аннан соң килгән сигезенче тоннар арасындагы интервалы („до" һәм аннан соңгы „до", „ля" һәм аннан соңгы „ля" һ. б.).

2. Ирләргә хас иң калын тавыш төре — бас.

3. *әд.* Шигырьдә үзенә махсус рифмалы сигез юллы строфа (беренче алты юлы ике чалыш рифма белән, соңгы икесе катнаш рифма белән берләшәләр).

ОКТА'ВАЧЫ *и.* Калын тавышка, октавага (2 мәгъ.) ия булган җырчы.

ОКТА'ЭДР *и. мат.* Өслеге сигез төзек өчпочмак белән чикләнгән җисем; сигезкырлык. *Октаэдрның күләмен табу.*

ОКТЕТ *и. муз.* Сигез мөстәкыйль тавыш яки уен коралы белән башкару өчен язылган музыкаль әсәр.

ОКТЯБРЯТ *и.* Пионерга керергә хәзерләнүче түбән (гадәттә 1 — 3) класс укучысы. — *Аны һәрбер октябрят белә инде: комсомол сафында кулак булырга тиеш түгел, — диде Рахманов.* М. Әмир.

ОКТЯБРИСТ *и.* 1905 елдагы 17 октябрь манифестыннан соң Россиядә төзелгән эре буржуазия һәм алпавытларның контрреволюцион партиясе члены яки шул партия тарафдары. *Беренче ноябрьда көндез өченче Дума ачылып, 371 тавыш белән рәислеккә октябрист Николай Хомяков сайланды.* Ф. Әмирхан.

ОКТЯБРЬ *и.* **1.** Календарь елның унынчы ае. *Өстәл өстендә, --- октябрь ахыры булуга карамастан, алсу чәчәкле гөлләр.* А. Шамов. *Җәйләр үтте, җиттек инде октябрьга.* Г. Тукай.

2. *(баш хәрефтән).* 1917 елгы Бөек Октябрь социалистик революциясе. *Киләчәккә юллар ачтык Бөек Октябрьда без.* Э. Исхак. *Октябрьның биргән бүләкләрен Тимер куллар белән саклыйбыз.* һ. Такташ.

ОКУЛИСТ *и.* Күз авырулары врачы, күз врачы.

ОКУЛЯР *и.* Оптик приборның күзәтү, карау өчен җайланган пыяласы (линза яки линзалар системасы). *Мөхәммәтнең өйрәнгән җитез куллары орудиене көйли башладылар, сул күзе кысылып, уң күзе панораманың окулярына текәлде.* Г. Әпсәләмов.

ОЛАГУ *ф. гади. с.* **1.** Әллә кая китеп югалу, юкка чыгу (яратмаган, юкка чыгуы теләнгән кеше хакында яки озак йөрүгә ачуланып әйтелә). *Хәтта аның эзләп таба алмаган Нажиясенә кул селтәп карый башлаган минутлары да булмады түгел; олаккан икән, олага бирсен.* Ф. Хөсни. *Кемдер аны ишектән керүгә: — Кая олагып йөрисең, хәлфә, нәкъ кирәк чакта... — дип, үз ротасына таба җитәкләде.* К. Нәҗми.

2. Өченче зат боерык фигыль формасында каргышлы теләкне белдерә: бетсен, юкка чыксын, кирәге юк; чәнчелеп китсен. *Моңарчы бит Рәхимнең беркайчан да эшендә сынатканы булмады. Олаксын барысы, китәм, шунда эшлим!* А. Расих.

ОЛАКТЫРУ *ф.* Кая да булса ераккa җибәрү; һәлак итү. *Олактырып мине чит илләргә, Ялгызымны ташлап киттегез.* Һ. Такташ. *Халит морза ниләр кылыр? — Егет башын олактырыр; Шулай уйлап хафалана Мәрхәмәтле газиз ана, Ике күзен чылата.* Ш. Маннур. || Берәр нәрсәне кая да булса аткару, юкка чыгару. — *Ни өчен сез, заводның эчке транспортын какшатып, бер паровозны олактырдыгыз?* Ш. Камал.

ОЛАН *и. диал.* **1.** *к.* бала. *Көтегез, көт, оланкайлар, дткәгез кайтмый калмас.* З. Мансур.

2. *күпл.* **оланнар.** Өлкән кешеләр зурларга якын итеп мөрәҗәгать иткәндә әйтелә: „туганнар“, „иптәшләр“ мәгънәсендә. — *Ярый, оланнар, бу тынгысыз карт эшебезне бүлдерде дип ачуланмагыз.* Р. Ишморат. — *Орлык ташырга ат көче җитми, чәчү сузыла... Бөтен ышанычыбыз сездә, булышыгыз, оланнар.* Г. Бәширов.

ОЛАНЛЫК *и. диал. к.* балалык (2 мәгъ.), балачак. *Оланлыкта азар, картайгач тәүбә итәр.* Мәкаль.

ОЛАУ I *и.* **1.** Нәрсә дә булса төяп илтү, йөк йөртү, кешеләр утыртып алып бару өчен атлы транспорт. *Олы юлдан олауда барган Газинурның шат һәм күңелле җыры ишетелә.* Г. Әпсәләмов. *Бүртә алашаны кунакта калдырдык та, пар атлы олау алып, җыенга чаптык.* Х. Кәрим.

2. *иск.* Бер олауга сыешлы йөк. *Ул - - - мичне төрлечә чыгара ала: аны, кышына ике олау гына утын ягып та, бөтен өй эчен май шикелле җылытырлык итәргә булдыра.* А. Шамов.

3. Йөк төялгән һәм бер-бер артлы тезелеп бара торган атлы транспорт төркеме. *Боз өстеннән, утыз километрга сузылган юл буйлап, героик шәһәргә азык төялгән олаулар агылды.* Г. Гобәй.

4. *сир. юн. килеш. форм.* Олаучы хезмәте. *Врангель офицерлары, чигенә башлагач та, әбинең улын аты-ние белән олауга алып киткәннәр.* Г. Бәширов.

Олау аты — йөк аты. **Олау арбасы** — йөк ташу өчен билгеләнгән арба. **Олау йөртү** — атлы транспортта кешеләр яки йөк ташу. **Олау (га) йөрү** — *к.* олау йөртү. *Күрәм: бергә олау йөргән дустым Мине танып килә елмаеп.* Х. Камалов. *Шуннан соң олауга йөреп күрсәтте инде Асылгәрәй: авылның бер очыннан кайтып керүе була, икенче очыннан чыгып та китә.* М. Шабай.

ОЛАУ II *ф. диал.* **1.** Ялгау, тоташтыру. *Өзелгән бауны олау.*

2. Ялгап озайту.

ОЛАУЛАП *рәв. сөйл.* Бик күпләп, йөге-йөге белән. *Таһир, чынлап та, балыкчы ул: - - - „Олы күл“ буенда туып үскән егет. Анда балыкны олаулап тарталар иде.* Ш. Маннур. — *Керәнлеләрдә халык бик эшчән. Менә шуңа да инде аларда ел саен уңышны олаулап бүләләр.* М. Мәһдиев.

ОЛАУЧЫ *и.* Олау I (1, 3 мәгъ.) йөртүче. *Газизә апа олаучыны кыстый-кыстый чәй эчерә һәм Габдулла турында сораштыра иде.* Ә. Фәйзи. *Йөк төягән олаучылар бик ашыкмыйлар.* М. Гафури. *Мин армиядә олаучы булып хезмәт иттем.* А. Расих.

ОЛАУЧЫЛЫК *и.* Олау йөртү шөгыле, хезмәте.

Олаучылык итү — *к.* олау йөртү.

ОЛАШУ *ф. диал.* Ялгану, тоташу. *Баскычтан төшеп, ун адымнар киткәч, салам белән япкан җыйнак кына келәт. Келәт белән олашынган таскак.* Т. Госман.

ОЛАШТЫРУ *ф.* „А“ авазын яки сүзнең „о“ авазыннан соңгы иҗекләрендә „ы“ авазын „о“ итеп әйтү. *Олаштыручы сөйләшләр.*

ОЛАЮ *ф. сөйл.* **1.** *к.* олыгаю. *Бала чакта олылардан курыксаң, олайгач балалардан куркасың.* Мәкаль. *Олая башлагач туган дуслыклар нигәдер ул хәтле бик тирәнәеп китә алмыйлар.* Ә. Еники.

2. *диал.* Зураю (күләм ягыннан). *Кояш калка диңгез кочагыннан, Ут тавыдай булып олаеп.* Ш. Маннур.

ОЛЕАНДР *и. бот.* Көньякта үсә торган тар яфраклы, хуш исле ак, алсу кызыл, сирәгрәк, сары чәчәкле мәңге яшел, агулы куак үсемлек; *к.* зәйтүн гөле. *Яр буендагы олеандр чәчәкләре алсу болытлар шикелле кабарып торалар.* Р. Мостафин.

ОЛЕИН *и. хим.* Төрле майларны таркатып алынган сыек май кислоталары катнашмасы (составының иң әһәмиятле өлеше олеин кислотасыннан тора).

Олеин кислотасы — туендырылмаган май кислотасы, күпчелек үсемлек майларының төп составын тәшкил итә.

ОЛИГАРХ *и.* **1.** Борынгы һәм урта гасырларда: олигархик хөкүмәт члены.

2. Эре монополистик капитал вәкиле.

ОЛИГА'РХИК *с.* Олигархиягә нигезләнгән. *Олигархик хөкүмәт. Олигархик идарә итү системасы.*

ОЛИГА'РХИЯ *и.* **1.** Борынгы һәм урта гасырларда бер төркем бай һәм дәрәҗәле кешеләрдән торган идарә, власть формасы; хакимлек итүче шундый кешеләр төркеме.

2. *күч.* Бер төркем империалистларның, эре монополистик капитал вәкилләренең политик һәм экономик хакимлеге. *Капиталистик монополияләрнең хуҗалык итүләре котылгысыз рәвештә финанс олигархиясенең хакимлегенә әверелә.* Политэкономия.

ОЛИМП *и.* Борынгы грек мифологиясендә: аллалар яшәгән урын, шулай ук аларның җыелышы, төркеме.

◇ **Олимп тынычлыгы** *кит.* — тулы, мәһабәт тынычлык. — *Сез артык пафос белән сөйләшәсез, ә фән аны яратмый, ул олимп тынычлыгын сөя.* А. Расих.

ОЛИМПИА'ДА *и.* **1.** Борынгы Грециядә регуляр рәвештә үткәрелгән олимпия уеннары бәйрәме арасындагы (ел исәбе буларак йөртелгән) дүрт ел вакыт.

2. Борынгы Грециядәге олимпия уеннары үрнәгендә һәр дүрт ел саен үткәрелә торган халыкара спорт ярышлары. *Бөтендөнья шахмат олимпиадасы.*

3. Гомумән спорт, сәнгать ярышлары: смотр, конкурс. *Математика олимпиадасы.* □ *Сәнгать олимпиадасын үткәрү өчен төзелгән махсус комиссиядән Хәерниса карчыкка, аның үз исеменә адресланып, хат килде.* Ф. Хөсни.

ОЛИ'МПИЯ *с.* Олимпия уеннары үткәрелә торган. *Без олимпия стадионында да булдык һәм аның 72 метр биеклектәге башнясыннан шәһәрне күзәтеп тордык.* Каз. утл.

Олимпия системасы — спорт уеннары үткәрү системасының бер төре: җиңелүче (кеше яки команда) ярыштан төшеп кала бара. **Олимпия уеннары** — 1) борынгы Грециядә Зевс алла хөрмәтенә дүрт елга бер үткәрелә торган бәйрәмдә гомуми спорт ярышлары; 2) борынгы Грециядәге олимпия уеннары үрнәгендә һәр дүрт ел саен үткәрелә торган халыкара спорт ярышлары.

ОЛИ'МПИЯЧЕ *и.* Олимпия уеннарында катнашучы. *СССРның олимпияче җыелма футбол командасы.* □ *Бокс буенча халыкара класслы ике мастер очрашуында олимпияче Виктор Запорожец көчлерәк булды.* Соц. Тат.

ОЛИФ *и.* Кайнатылган үсемлек (җитен, киндер һ. б. ш.) мае — майлы буяу (лак хәзерләү өчен кулланыла). *Буяуга олиф кушу.*

ОЛПАТ *с.* Җитди, дәрәҗәле, бөек. *Аксакалларың-дай олпат, Акыллы син татар теле.* Н. Нәҗми. *Азамат — ул мәшһүр, дәрәҗәле һәм хәтта олпат шәхес.* Каз. утл. || *и. мәгъ.* Бөеклек, мәһабәтлек. *Күрәм, үз олпатын бозмый саклап, Урал ята әкрен, тын гына.* Ш. Бабич.

ОЛПАТЛЫК *и.* Җитдилек, дәрәҗәлелек, бөеклек. *Күтәргән йөге генә түгел, күңелен айкаган кичерешләре шулай хәрәкәтенә олпатлык, сабырлык өстәде.* Каз. утл.

ОЛТАН *и.* Аяк киеменең табан формасындагы аскы өлеше (махсус өлгедә киселә һәм тегеп яки кагып беркетелә). *Киез итеккә олтан салу.* □ *Аягыңдагы итегең болгар икән олтаны; Сине сөйми кемне сөйим, Син бит егет солтаны.* М. Фәйзи.

◊**Олтан бит (йөз)** — оятсыз, намуссыз. [*Бибкәй Хаҗиягә:*] *Их... оятсыз, олтан бит! Күпме яшь кызларны минем күз алдымда башка илләргә сатып җибардең!* Т. Гыйззәт. — *У, җир бит! У, олтан йөз! --- Эт симерсә, иясен тешли, шул буладыр инде.* К. Нәҗми. **Олтан булу** — буйсынып, кимсетелеп яшәү турында. *Кеше иленда солтан булганчы, үз иленда олтан бул.* Мәкаль. **Олтанга әйләндерү** — үзенә буйсындыру, ихтыярсыз кеше итү. *Бу йортка төшеп, ике ай үтмәде, Сабира аның җилкәсенә менеп атланды, көндәшен бөтенләй олтанга әйләндерде.* Г. Ибраһимов.

ОЛТАНЛЫ *с.* Олтан салынган. *Олтанлы киез итек.*

ОЛТАНЛЫК *л.* 1. Олтанга яраклы, олтан салу өчен кирәкле материал. *Олтанлык сатып алу.* || *к.* олтан. *Соңыннан ул олтанлык тегәргә, иске киез итекләрне ямарга өйрәнде.* Ш. Еникеев.

2. *с.* Олтанга яраклы, олтан өчен файдаланыла торган. *Бака яфрагы олтанлык тиреләрне бик яхшы или.* Робинзон әзл.

ОЛТЫРАК *и.* Махсус өлгедә киселеп, аяк киеменең эченә салына яки олтанга эчке яктан беркетелә торган юка күн, киез, катыргы яки материя кисәге. *Сиражи абзый --- зур кайчы белән иске тула оек балтырыннан чабата олтырагы кисеп утыра иде.* М. Галәү. *Хәйдәр, аягындагы сандал олтырагы астыннан алып, Хәбибкә дәфтәр битенә язылган язу бирде.* Г. Минский.

◊**Олтырагына да тормау** — кемнән дә булса берәр яктан чагыштырғысыз түбән, начар булуы турында әйтелә. **Олтырак бит (йөз)** — *к.* олтан бит. *Бу хәтле халыкның бу кадәр бердәмлек белән торулары кемнәрне каушатмас. Ахырда чиновникларның олтырак йөзләрендә --- җыерчыклар йөгерешеп уздылар.* Х. Кәрим. **Олтырак булу** — *к.* олтан булу. *Газимә абыстаң Галиәкбәр хәзрәткә әлгәрге шикелле олтырак булып тормый соңгы елларда.* Г. Мөхәммәтшин. **Олтырак итү** — *к.* олтанга әйләндерү. — *Бара-тора олтырак итәр әле үзеңне* [*Рәхилә*]. М. Шабай. **Олтырак үбү** — бик зур түбәнчелек күрсәтү, ялыну-ялвару. *Хәкимов мөфтинең кәвеш олтырагын үпкәч, мөфти, губернаторга хат язып, татарча театр уйнауны* [*тыйды*]. Ш. Мөхәммәдев.

ОЛТЫРАКЛЫК *и.* 1. Олтырак өчен материал. *Олтыраклык кисеп алу.*

2. *с.* Олтыракка яраклы, олтырак өчен файдаланыла торган.

ОЛУГ *с. кит.* 1. *к.* бөек. *Олуг революцияләр күп корбан талап итәләр һәм күп корбан алалар.* Ф. Әмирхан. *Олуг ханым! Күп сугышлар өчен Бүләкләнде гаскәр башлыгы.* Ф. Бурнаш.

2. *к.* олы. [*Гыйльми:*] *Сабыр, килен. Үгет-нәсихәтне тыңларга, олугларны санларга кирәк.* Т. Гыйззәт. *Авылда булачак зур үзгәрешләр, тормышка ашырылачак олуг бурычлар турында Вәлиев --- ишетеп белә иде инде.* С. Рафиков.

◊**Олуг җанлы** — *к.* олы җанлы. *Эзлимен шунда олуг җанлы кеше, Бар кешеләрдән дә вөҗданлы кеше.* М. Гафури.

ОЛУГЛАУ *ф. кит.* Ихтирам итү, хөрмәтләү, зурлау. — *Рәхмәт, Түләк, мине олугладың.* Н. Исәнбәт.

ОЛУГЛЫК *и. кит.* Зурлык, мәртәбәлек; олуг (1 мәгъ.) булу хәле. *Һәр олуглар эшләгәнлектән олуглыклар таба.* Г. Тукай. — *Кара әле, бабай. син бу көннәрнең олуглыгын, шатлыклылыгын сизәргә тиешсең.* Ш. Усманов.

ОЛУГЛЫКЛЫ *с. кит.* Мәһабәт, тантаналы. *Айның диңгезгә төшкән шәүләсе җир белән күкне тоташтырган нур күпере шикелле һәм гажәп матур, һәм олуглыклы иде.* Ф. Әмирхан.

ОЛЫ *с.* 1. Яшь ягыннан зуррак, алданрак туган. *Без [Гасыйм] белән кордашлар да әле: ул миннән ярты яшькәме, әллә өч чирек яшькә генәме олы.* Ш. Маннур. *Гөлҗамал олы кызын тиз генә уятты да, сыерын савып бетерергә кушып, үзе Хәлим белән чыгып китте.* И. Гази.

2. Өлкән, зур (яше, эш тәжрибәсе, хезмәт урыны һ. б. яклардан). *Олы буын язучылардан бигрәк тә Г. Ибраһимов иҗатында яңа герой проблемасы үзенең бик әһәмиятле яклары белән куелды.* Г. Халит. — *Нургали абый, кызмыйча гына сөйләшик: без олы кешеләр.* Ә. Еники. || *и. мәгъ.* Зур кеше, өлкән кеше, карт кеше. *Бер олының сүзен тыңла, Бер кеченең сүзен тыңла.* Мәкаль. *Тимери, олыларның ни әйтәсен көтеп, сүзсез генә басып торган киленә күз төшереп алды.* Г. Бәширов.

3. *сөйл.* Күләм, озынлык, эчтәлек ягыннан үз ишләреннән зур. *Олы урамга чыгу.* □ *Су өстендә кечкенә-кечкенә пароходлар, бөтен көчләре белән тырышып, үзләренә ана булырлык олы-олы баржалар тарталар.* Ф. Әмирхан. *Ул арада сәгатьнең олы теле унберенче ярты өстенә килеп басты.* М. Гали. *Беркөнне район үзәгендәге олы магазинга бардым.* Г. Галиев.

4. Абруйлы, дәрәҗәле, ихтирамлы. — *Кечелектән олы булган кеше һәркем алдында да мактаулы.* Ф. Бурнаш. *Чакырып килгәннең аты олы, Чакырмыйча килгәннең хакы олы.* Мәкаль. || Талантлы, бөек. *Тукай — безнең иң олы кешебез.* Г. Ахунов. || *күч.* Югары, өстен. — *Аштан олы түгелсең бит, Шәрифулла туган, — диде карчык, — утыр, безнең нигъмәттән дә авыз итеп кара.* А. Шамов. *Адәмнән олы ат юк, икмәктән олы аш юк.* Мәкаль.

5. Әһәмияте, файдасы зур булган; зур мактауга, ихтирамга лаеклы. *Олы максат белән яшәү.* □ *Жаның олы булса — һәр эшең олы.* Мәкаль. *Бу — синең олы хезмәтең булыр; Без куйган йолдыз нур сибеп торыр!* З. Маннур. || Әһәмиятле, бик җитди. *Теге вакытта сафка баскан һәр скважина безнең*

тормышта олы вакыйга иде. Р. Төхфәтуллин. — *Әгәр вакыт таба алсагыз, бер олы киңәш бар иде, иптәш мастер.* Р. Ишморат.

6. Көче, интенсивлыгы белән аерылып торган; тирән, көчле, зур. *Олы тойгы. Олы шатлык. Олы мәхәббәт.* □ — *Әйтмәгез дә, ишетмим дә. Шундый олы куанычлы көндә самовар гөрләтмәскә, әллә син теге.* С. Рафиков.

Олы авыру үләне — *к.* эт җиләге. **Олы ана** *иск.*— борынгы чорда гаилә, ыруг башлыгы. **Олы аналык чоры** *иск.* — *к.* матриархат. **Олы ата (й)** *иск.*—аксакал. *Илнең башы олы атай Бурангыл карттан да болар хакында кимсетеп әйтелгән сүз чыкмады.* Г. Ибраһимов. **Олы аталык чоры** *иск.*— *к.* патриархат. **Олы итү** — олылау, хөрмәт күрсәтү. — *Безнең якташлар олыларны олы итә белә́ләр.* Ю. Әминов. **Олы кош** *зоол.* — тилгәннән зуррак ерткыч кош, бөркет. **Олы хатын** *иск.* — күп хатынлы семьяда карт хатын, беренче хатын. **Олы юл** — 1) эре торак пунктлар арасындагы киң юл; тракт. *Бу йорт олы юлдан байтак читтә, урманның куе бер җирендә.* Г. Гобәй; 2) үзәк, магистраль юл. *Телеграмм баганасы олы юлга маяк ул.* Җыр. *Төнлә белән олы юлны немец бомбага тот[ты].* Ә. Еники; 3) *күч.* нәрсәнең дә булса үсешендә, алга барышында төп, берәр төрле максатка ирешүдә дөрес юнәлеш. *Олы юлда көрәшергә сүзе калды, Җиңү юлын күзәтергә күзе калды — Партиядә гәүдәләнеп Үзе калды.* Ф. Бурнаш. *Үзем омтылган олы юлга әле генә аяк басып киләм икән.* Г. Бәширов. **Олы як** — өйнең зур бүлмәле ягы, түр ягы. *Аларның өендә, олы якларында, бәләкәй генә бер рам эчендә мөлаем карашлы, чибәр генә бер егетнең рәсеме эленеп тора иде.* Э. Касыймов. **Олы торыклы**— *к.* озын торыклы. *Дүрт бүлмә юыртырга керешкән олы торыклы, зур алдырыклы туры атның дилбегәсен бушатыбрак җибәрде.* С. Рафиков.

◇ **Олы авыз** — күп сөйләргә, кирәк-кирәкмәгәнне сөйләргә яратучы кешегә карата әйтелә. *Юл клубка иде. — Эх, Җамали кияү! — дип, Ерылган олы авызлар Ярты юлдан каршы алдылар.* М. Җәлил. *Шәрифуллин олы авызны [Солтанны] тыныч ландырырга теләде.* С. Рафиков. **Олы башы(гыз) белән** —1) балаларча беркатлы, уйлап тормыйча теләсә нәрсә сөйләүче өлкән яшьтәге кешегә ачу-үпкә, ризасызлык хисләре белдереп әйтелә. *Аның бу сүзләре - - - олы башы белән авызын ерып көлеп торучы Гата картка яшен суккан кебек тәэсир итте.* Н. Фәттах; 2) үзенең өлкән, тәҗрибәле кеше булуын авторитет, дәрәҗә итеп күрсәтү өчен кулланыла. *Олы башым белән ялганлап тормам инде.* **Олы башны кече итеп** — 1) кече күңеллелек, түбәнчелек күрсәтеп. *Бала чактагы дуслыклар буенча [Фазыл], олы башын кече итеп, безне һаман да үз күрә, якын күрә.* Г. Ибраһимов. [*Хуҗа:*] *Хуш, олы башыгызны кече итеп килгәнсез, инде олы саныгызны кече итеп утырыгыз.* Н. Исәнбәт; 2) бала-чага, яшь-җилкенчәк шикелле беркатлыланып; дәрәҗә, абруй төшереп. — *Илләмәгәр, ахирәт, олы башыңны кече итеп, кеше гайбәтен җыеп йөрмәс идең.* Ф. Хөсни. **Олы йомыш** — организмның туры эчәк аша тизәк бүлеп чыгару ихтыяҗы. **Олы күтәрү** — булдыра, башкарып чыга алмаслык эшкә тотыну. *Ормас олы күтәрер.* Мәкаль. — *Юкка гына син олы күтәреп маташасың, Гөлсинә ...* Р. Ишморат. **Олы сабый** — олы яшьтәге акылга җиңел, дивана кеше турында. [*Идият*] — *авылның олы сабые, берәүгә дә зыяны тими торган саф күңелле, җор сүзле диванасы.* Ш. Маннур. **Олы сөйләү (сөйләшү)**— мактанып, шапырынып сөйләү (сөйләшү). *Олы сөйләгәнче, олы телем икмәк аша.* Мәкаль. **Олы юлга чыгу** — үсеш, алга барыш, максатка ирешү өчен төп, дөрес юл, юнәлеш табу. — *Олы юлга чыкты безнең Гәрәй.* К. Нәҗми. **Олы җан иясе** — *к.* олы җанлы. *Габделбәрнең - - - беренче кайгылы сүзе Артем Семенович турында булды. — Олы җан иясе иде мәрхүм, күңеле бигрәк пакь иде.* М. Шабай. **Олы җанлы (йөрәкле)**— эчкерсез, киң күңелле, кешелекле. — *Дниең рәхмәт инде, булса булыр икән шундый олы җанлы кеше.* Э. Касыймов. — *Мин сине олы йөрәкле, кыю егет дип йөрсәм, син, Әнвәр, вак җанлы мещан икәнсең...* Р. Ишморат. **Олы җанлылык** — эчкерсезлек, киң күңеллелек, кешелеклелек. *Харрасның миңа карата булган олы җанлылыгын, минем исән калуыма сәбәпче булуын ишеткәч, ул миңа аерата якын булды.* Ә. Айдар. **Олыга китү** — *к.* зурга китү. — *Ул шулай икән, дхнәф туган. Бары да кечкенәдән башлана. Башта әзләп-әзләп кенә эчәсең. - - - Аннары олыга китә.* С. Рафиков. **Олыдан кубу** — чамадан арттыру; тыйнаклык, мөмкинлек чигеннән чыгу. *Айдар - - - бик олыдан купмыйча, әле тик болай гына кызыксынган бер төс белән, колхоздагы хәл-әхвәлне сорашты.* Ф. Хөсни.

ОЛЫГАЮ *ф.* Өлкәнәю, олы кешегә әйләнү, картаю. *Мин үзем бик артык зирәк кешеләрдән түгел, яшем олыгайгач, хәтерем чуала төшкәндер инде.* М. Гали. *Сәлимә бераз олыгая, аның йөзендә бертөрле уйчанлык сизелә башлый.* Ф. Әмирхан.

ОЛЫ-КАРА *җый. и. к.* олы-кары. *Олы-кара, бигрәк тә хатын-кыз, шулай ук бик сәерсенеп, ул үткәндә күздән югалганчы туктап карап кала иде.* Ф. Хөсни. — *Бик рәхмәт! Алай олы-карага илтифатлы булгач, бик рәхмәт, — дип, кабат-кабат әйтте Дәүли.* С. Рафиков.

ОЛЫ-КАРЫ *җый. и.* Олы яшьтәге кешеләр. *Хатын-кыз, яшүсмер һәм олы-карыны сугышның котылгысыз кыенлыкларына каршы кыюлык белән җитәкләп барырга, фронтка күп итеп икмәк җитештереп бирергә кирәк иде.* Г. Бәширов.

ОЛЫЛА'РЧА *рәв.* Олы (2 мәгъ.) кешеләргә хас булганча. *Бу вакытта Илсөяр балаларча шатлана, олыларча фикер йөртә, маякларны ничек күчереп кую турында уйлый иде.* Г. Гобәй. — *Син, Җиһан, хайванны алай ачуланма, — диде Нургали, олыларча акыл биреп.* Ә. Еники.

ОЛЫЛАУ *ф.* 1. Хөрмәтләү, тирән ихтирам күрсәтү. *Олыласаң олыны, олыларлар үзеңне.* Мәкаль. *Мин олылыйм сезне, кешеләр! Сез — тормышта асыл энҗеләр.* М. Хөсәен. || *рәв. мәгъ.* **олылап.** Хөрмәтләп, ихтирам итеп. *Шәмәрдән — әле ир уртасына да җитмәгән бер кеше. Ләкин - - - җитезлеге өчен аны „абзый" дип олылап әйтмичә булмый.* Ф. Хөсни.

2. Мактап, горурланып искә алу. *Олылый һәрбер бөек ил Үзенең үткәннәрен.* Х. Туфан. *Безнең күңеллә ребездә аңа карата бары тик чиксез хөрмәт һәм олылау гына калды...* А. Шамов. || *рәв. мәгъ.* **олылап.** Мактап, горурланып. *Без ул батырларны хөрмәт белән һәм олылап искә алабыз.* Ә. Исхак. || Тантаналы рәвештә хөрмәтләү. *Хөкүмәт [Галиәкбәр абзыйны] Хезмәт батыры исемен биреп олылады.* Г. Кутуй.

ОЛЫЛЫК *и.* 1. Яшь ягыннан зурлык, өлкәнлек. *Бу секундта Хөсәеннең йөзе үтә җитдиләнеп киткән, аның яшь чыраена олылык кергән иде.* А. Расих. *Шәрифә бераз кыркурак та, теллерәк тә булып китә, ләкин Рәүфә моны аның чит күрүе итеп түгел, ә олылыгы итеп хисаплый иде.* А. Шамов.

2. *сөйл.* Зурлык (күләм ягыннан). — [*Съездга*] *бардым. Безнең авылның барлык өйләрен бергә өйсәң дә аның олылыгына җитмәслек бер әкәмәт олы йорт күн киемле - - - егет утыра минем янда.* С. Рафиков.

3. Дәрәҗә, абруй; хөрмәткә, ихтирамга лаеклылык. *Олылыгың арткан саен, кечелегең артсын.* Мәкаль. *Инде сакалы ап-ак булып, яше җитмешкә җиткән карт һаман да ил эчендә үзенең олылыгын саклап килә алды.* Г. Ибраһимов. || Соклану, хөрмәт тудыра торган гүзәл сыйфат. *Бөтен гомерләрен хезмәткә багышлаган карт эшчеләрдә үзләренә генә хас ниндидер бер матурлык, олылык бар.* Г. Әпсәләмов.

4. *күч.* Зурлык, бөеклек. *Бу карашта Булат тойды Йөрәгендә җылылык, Бирде аңа ул олылык, Тормышына тулылык.* М. Җәлил. [*Инсаф*] *авылда яшәп карасын. Тир түгеп икмәк үстергәнне күрсен. Хезмәтнең тәмен, олылыгын татысын.* Г. Мөхәммәтшин.

ОЛЫЛЫ-КЕЧЕЛЕ *с.* 1. Төрле яшьтә булган, олы һәм кече яшьләрдәге. *Гыйльмениса түтинең --- кечкенә өендә иртәгесен олылы-кечеле ике чәйнек утыртылган --- көмеш ак поднос иде.* Каз. утл.

ОЛЫЛЫКЛЫ *с.* Ихтирамга лаек, абруйлы. *Әнә агарган сакаллы, көмеш чәчле, олылыклы зур доктор... Ул нинди рәхимле, нинди түбәнчелекле.* Г. Ибраһимов.

ОЛЫСЫ-КЕЧЕСЕ *җый. и.* Төрле яшьтәге кешеләр: олылар да, яшьләр дә, кечкенәләр дә. [*Авылның*] *олысы-кечесе гитлер яуларын җиңеп кайтучыларны каршыларга чыккан, кулларында чәчәкләр, күзләрендә шатлык яшьләре иде.* Г. Гобәй.

ОЛЫСЫМАКЛАНУ *ф.* Олыгайгандай булу; үзен олыларча тоту, олыларча кылану. — *Безнең апайлар монда, ничектер, үзгәреп, олысымакланып киткәннәр димме?* Г. Бәширов. [*Сабирның*] *олысымакланып кына мине дә үзе белән бергә кушып куюы минем яңадан ачуымны китерде.* Н. Исәнбәт.

ОМ *и. физ.* Электр каршылыгын үлчәү берәмлеге.

ОМАР *и.* Диңгездә яши торган зур кысла. *Хуан Фернандес утрауларының халкы күп түгел — нибары 450 ләп кеше. Алар балык һәм омар тоту белән шөгыльләнәләр.* Робинзон әзл.

ОМЕ'ГА *и.* Грек алфавитында соңгы хәреф.

ОМЛЕТ *и.* Әз генә он кушып, сөткә болгатып пешерелгән йомырка тәбәсе.

ОММЕТР *и.* Электр үткәргечнең токка булган каршылыгын үлчәү приборы.

ОМО'ГРАФ *и. лингв.* Язылышы бердәй, әйтелеше (фонетик яңгырашы) төрле булган сүзләр (мәсәлән: **койка'** [койка] — ашамлык, **ко'йка** — карават; **тир** — тире асты бизләре бүлеп чыгара торган үтә күренмәле сыеклык, **тир** — ату күнегүләре үткәрә торган урын).

О'МОЛЬ, О'МУЛЬ *и.* Сөләйман балыклар семьялыгына керә торган ак балык (Төньяк Боз океаны бассейнында һәм Байкал күлендә очрый; уылдык чәчү өчен елгага керә). *Омоль балыгы өчен хәтта Байкалга барып җиткәнем бар.* Ш. Маннур.

ОМО'НИМ *и. лингв.* Язылышлары һәм әйтелешләре бердәй, ләкин мәгънәләре бөтенләй башка булган сүзләр (мәсәлән: **йөз** — сан, **йөз** — исем, **йөз** — фигыль). *Омонимнар сүзлеге төзү.*

ОМОНИ'МИК *с. лингв.* Омоним булган. *Омонимик сүзләр. Омонимик рифмалар.*

ОМОНИ'МИКА *и. лингв.* 1. Нинди дә булса бер телнең омонимнар җыелмасы. *Татар теленең омонимикасы.*

2. Лексикологиянең омонимнарны өйрәнә торган бүлеге. *Татар тел белемендә омонимика.*

ОМОНИМИ'Я *и. лингв.* Төрле мәгънәдәге сүзләрнең авазлар тәңгәллеге.

ОМОФОН *и. лингв.* Язылышы төрле, әйтелеше бердәй сүзләр (мәсәлән: **таркала — тар кала, кызса — кысса** һ. б.).

ОМТЫЛУ *ф.* 1. Бик кызу рәвештә берәр якка таба хәрәкәт итү, ыргылу, ташлану. *Улем уты сибеп дошманга, Алга омтылабыз, гел алга.* Ф. Кәрим. *Һавадагы карга, давылга очраган күбәләктәй, арлы-бирле талпына да, канатларын җыеп, таш кебек җиргә омтыла.* И. Гази. || Кем яки нәрсәгә таба кискен гәүдә хәрәкәте ясау. *Туташ озын, зифа буе белән алга таба омтылды. Урмановка йомшак, нечкә кулын сузды.* Г. Ибраһимов. *Газинур, бөтен гәүдәсе белән омтылып, Буранбайның кечкенә кара күзләренә карады.* Г. Әпсәләмов. || Нәрсә дә булса эшләргә тырышып, берәр төрле хәрәкәт ясау. *Ул аягына басарга омтылды, тик аның винтовкасы таеп китте дә чак кына егылмыйча калды.* Г. Бәширов.

2. Берәр максатка ирешергә тырышу; ныклы карар белән берәр нәрсәне тормышка ашырырга тырышу. *Эшлә, уйлан. Матур хыял белән Омтыл, ашкын, ireш максатка.* Ш. Мөдәррис. *Алар үзләренең өстенә бурыч итеп куелган бишьеллык планны --- өч елда үтәргә омтылалар.* Һ. Такташ. || Берәр нәрсә эшләргә теләк барлыкка килү (сүз барышында, берәр эш барышында). *Хисамның һаман да нәрсәдер сөйләргә омтылуын күреп, кулымны аның иңбашына салдым.* А. Шамов. *Аларның шаярулы яисә төрле мәгънәләргә тартымлы сүз куертырга омтылуларына [Мәдинә] кискен, хәтта тупас һәм ачы җаваплар кайтара.* Ш. Камал. || *күч.* Талпыну, ашкыну, атлыгу (йөрәк, күңел турында). *Күңел матур киләчәккә таба ашкына вә омтыла.* Ф. Әмирхан. *Туган кырларының шатлыгына, Ах, ничек соң йөрәк омтылмас?* Ш. Маннур.

ОМТЫЛУЛЫ *с.* Омтылу (2 мәгъ.) билгеләре ачык чагылып торган. *Омтылулы караш.* || *рәв. мәгъ.* Нәрсә дә булса эшләргә омтылып. *Көннәрем дә шулай ук ашкынулы, омтылулы һәм тынгысыз үтә иде.* Р. Төхфәтуллин.

ОМТЫЛУЧАН *с.* Нәрсә дә булса эшләргә, нәрсәгә дә булса ирешергә омтылып, ашкынып, атлыгып торган. *Ул киләчәк өчен яшәүче, үзенең аңлы тормышы башланып киткәннән бирле, алдынгы идеяләр белән рухланып, гел алга омтылучан кеше иде.* Г. Бәширов.

ОМТЫЛУЧАНЛЫК *и.* Омтылучан булу сыйфаты. *Дсәрләрнең һәммәсендә дә булган тормыштан ризасызлык, яңа, яхшы тормышка омтылучанлык, шуны эзләргә тырышучанлык бар.* Г. Нигъмәти.

ОМТЫЛЫШ *и.* 1. Нәрсә дә булса эшләргә тырышып ясалган хәрәкәт. *Чыннан да, ул атыннан төшми һәм төшәргә дә бер омтылыш ясап күрсәтми иде.* А. Шамов. *Бикмуш бабай --- комга тезләнде, аяклларына басар өчен омтылыш ясады.* Г. Гобәй.

2. Нәрсәгә дә булса ирешергә, ия булырга омтылучанлык; актив максат, теләк, ният. *Гыйльми эшкә омтылышны миңа еллар алып килде.* А. Расих. *Безнең омтылыш: кешелектә сыйныфлар бетсен.* Ф. Кәрим.

3. Уңышлы барып чыгуына тулы ышаныч булмавын аңлаган хәлдә, тәвәккәллек итеп, нәрсә дә булса башкарырга яки нәрсәгә дә булса ирешергә юнәлтелгән эш-хәрәкәт; тәжрибә характерындагы башлангыч. [*Бу әсәрне*] *безнең татар Совет драматургиясендә бүгенге көн темасына күңелле комедия тудырырга беренче омтылыш дияргә мөмкин.* М. Җәлил.

ОМТЫЛЫШЛЫ *с.* 1. Нинди дә булса омтылыш белән яшәүчән, нәрсәгә дә булса омтылучан. [*Муса*] *бик җыйнак, максатка омтылышлы һәм ныкышкын ихтыярлы кеше була.* Р. Мостафин. *Мөлаемлеге, сүзгә*

тапкырлыгы һәм чын күңеллелеге белән ул безнең рухи дөньябызны баета, күңелләрне сафландырып, омтылышлы, канатлы итә. Г. Ахунов. || Максатчан, нинди дә булса максатка юнәлтелгән. *Хәзерге әдәби образларның аңнары, тормышка карашлары --- киң һәм омтылышлы.* Л. Җәләй.

2. Тизлеге белән аерылып торган; җитез, кискен. *Омтылышлы хәрәкәтләр белән бию.* | *рәв. мәгъ. Дивизия бервакытта да чигенмәде, һөҗүмдә омтылышлы хәрәкәт итте.* Каз. утл.

ОМТЫЛЫШЛЫЛЫК *и.* Омтылышлы булу сыйфаты. *Максатка омтылышлылык.*

ОМТЫЛЫШСЫЗ *с.* Дәртсез, пассив. *Боек, сулпән, омтылышсыз була Хыялсыз көн иткән һәр кеше.* Ф. Кәрим.

ОМТЫЛЫШЧАН *с. к.* омтылучан.

ОМТЫЛЫШЧАНЛЫК *и.* Омтылышчан булу сыйфаты. *Артист --- образның эчке җылылыгын, эмоциональ байлыгын, омтылышчанлыгын тиешенчә ачып җиткерми.* М. Җәлил.

ОМША'НИК *и. махс.* Бал кортларын кышлату өчен җылытылган махсус корылма, йорт. *Уң якта кортлар кышлый торган омшаник. Сулда кортчы Апанасның торак бүлмәсе.* Т. Гыйззәт.

ОН *и.* 1. Башаклы ашлык бөртекләрен тегермәндә тарттырып яки төеп алынган порошок сыман ашамлык әйбере. *Арыш оны. Кукуруз оны. Бодай онынан камыр кую. Он иләү.* □ *Тегермәндә арыш, бодайлар онга әйләнәләр. Ә ул оннан әни безгә күмәч салып бирә.* А. Алиш. || Гадәттә ачлык вакытта ашау яки мал азыгы өчен төрле җимеш, үләннәрдән һ. б. ш. хәзерләнгән әйбер. *Алабута оны. Шомырт оны. Кайры оны. Печән оны.*

2. Порошок итеп изелгән минераль матдәләр. *Сөяк оны. Бәрәңге оны. Фосфор оны.*

Он ашы — *к.* камыр ашы. **Он корты** — онга кереп үрчи торган корт; *русчасы:* червь мучной. **Он суы** — сыек апара (малга эчерү яки ачлык вакытта ашау өчен).

◇ **Он суы да, тоз суы да юк (чыкмый)** — *к.* йон да юк, ит тә юк. *Аны белгән кешеләр, Габдрахман улы Габдрәхимдә он суы да, тоз суы да юк, әллә кемгә охшаган ул, диләр иде.* Ш. Әхмәдиев.

ОНАНИЗМ *и.* Җенси теләкне табигый булмаган юл белән үтәү; кул зинасы.

ОНДА'ТРА *и.* Куе көрән төстәге кыйммәтле мех бирә торган кимерүче җир-су җәнлеге (су күсесе); шул җәнлекнең мехы. *Икенче көнне Марс кармагына өтек кенә бер ондатра килеп капты. Балыкчының йөрәген алган җәнлек шул үзе иде.* Мәр. Рафиков. || *с. мәгъ.* Шул җәнлекнең мехыннан эшләнгән. *Ондатра бүрек. Ондатра яка.*

О'НИКС *и.* Ак һәм кара төстәге катламнардан торган минерал; ахакның бер төре.

ОНКО'ЛОГ *и.* Онкология белгече — врач.

ОНКОЛО'ГИК *с.* Онкологиягә караган, онкологиягә бәйләнешле. *Онкологик тикшеренү.*

ОНКОЛО'ГИЯ *и.* Медицина фәненең шешләрне һәм аларны дәвалау методын өйрәнә торган бүлеге. *Онкология институты.*

ОНЛАНУ *ф.* Онга буялу. *Кием онлану.*

ОНЛАТА *рәв.* Он хәлендә. *Бурычны онлата түләү.*

ОНЛАУ *ф.* Онга буяу, онда әвәләү. *Гөлбану --- куна такта өстендә камырны зур-зур икмәкләр ясап әвәләде, онлады да кызу мичкә тыкты.* Г. Ибраһимов.

ОНЛЫ *с.* Онланган, онга буялган; он салынган, тутырылган. *Камыр басып торган бер хатын --- онлы кулларын сөртә-сөртә: — Апаларым, сезгә кем кирәк иде? — дигән сөальне бирде.* М. Гафури. *Фатыйма, онлы капчыкны алып, Маликларга үзе китте.* И. Гази.

ОНЛЫК *с.* 1. Онга, он итеп тарттырырга дип билгеләнгән. *Гайнетдин бабай, чанага туры атны җигеп бетергәч, келәттәге онлык --- өч тулы капчык һәйбәт, чүпсез богъдайны чыгарып салды.* Ак юл.

2. Он алырга җитәрлек. *Белмәссең, бәлкем, бераз онлык акча да юнәтеп кайта алырмын әле.* Г. Гобәй.

ОНОМА'СТИКА *и. лингв.* 1. Тел белемененең ялгызлык исемнәрне өйрәнә торган бүлеге.

2. Тел белемененең кешене атау категорияләрен (исем, атасының исеме, фамилия, псевдоним һәм кушаматларны) өйрәнә торган бүлеге; антропонимика. *Без биредә тел гыйлеменең ономастика, язъни кеше исемнәре турындагы бүлегенең кайбер төшенчәләрен популяр рәвештә бәян итмәкче булабыз.* Ф. Фасеев.

ОНТА *и. диал.* Он тузаны. *Сүтәләр өч ташлы тегермәнне. --- Онта коела, күксеп беткән онта.* С. Хәким.

ОНТОГЕНЕЗ, ОНТОГЕНЕ'ЗИС *и. биол.* Хайван яки үсемлек организмының барлыкка килүдән алып соңгы яшәешенә кадәр булган индивидуаль үсеше. *Онтогенезның --- төр үсешен кабатлавы нәселдәнлек белән тыгыз бәйләнештә тора.* А. Тимергалин.

ОНТОГЕНЕ'ТИК *с. биол.* Онтогенезга бәйләнешле; хайван һәм үсемлек организмының индивидуаль үсеше белән бәйләнгән. *Онтогенетик тикшеренү.*

ОНЧЫ *и.* Он белән сату итүче. *Атаклы ончы Арсланов үзе үк булмаса да, шулар компаниясенә зур гына өлеше булган --- кеше булып чыкты бу [купец].* Ф. Хөсни. *Базарларда ончыларның --- гына эшләре яхшы бара.* М. Галәү.

ОНЧЫЛ *с.* 1. Составында он яки крахмал (күп) булган.

2. Онга охшашлы, он сыман. *Ончыл куныклык.*

3. Төсе белән онны хәтерләтә торган; ак.

Ончыл чык — яфракларында, сабакларында ак куныклык барлыкка килү белән характерлана торган үсемлек авыруы. *Җиләкләрне үсемлек бетләре, --- ончыл чык, ак таплылык һ. б. зарарлый.* Йорт эшләре.

ОНЫК *и.* Улының яки кызының баласы. *Бабасы яшел җимеш ашаганга, оныгының теше камашкан.* Мәкаль. *Бер карт белән карчык кызларын кияүгә бирәләр. Өч ел гомер үтә, оныклары һаман юк та юк.* З. Нури.

ОНЫТУ *ф.* 1. Кем яки нәрсәне игътибар үзәгендә тотмау; хәтердән чыгару, күңелдә сакламау, искә төшермәү. *Дусларын онытканның үзен дә онытырлар.* Мәкаль. *Марат, әнисе үлгәнгә ел ярым дигәндә, аңар бәйле хатирәләрне тәмам онытып бетереп, бөтен барлыгы белән Гөлсем апага бирелгән иде инде.* Г. Гобәй. || Истән чыгарып җибәрү, кирәк вакытта (әйтү, сөйләү, эшләү һ. б. өчен) хәтергә төшерә алмау. *Ул үзләрен озатып калган әтисе, әнисе, әбисе һәм абыйсы белән дә исәнләшергә онытты.* М. Гали. *Мин, әйтергә теләгән фикеремне онытып, авызымны ачкан килеш аптырап калдым.* М. Әмир. || *күч.* Нәрсә белән дә булса исәпләшмәү, игътибар итмәү, ваемсызлык күрсәтү. — *Син минем совет баласы икәнемне онытма. Беләсеңме, хәзер сезне яклаучы патша җәһәннәмнең төбенә китте.* М. Фәйзи.

2. Очраклы рәвештә калдыру, үзең белән алмау. *Утырабыз икәү, мин яулыкны Калдырганмын онытып өемдә.* М. Җәлил. *Аның күзләре өстәл кырыенда Хәйри онытып калдырган пәкене күрделәр.* Г. Минский. || *рәв. мәгъ.* **онытып.** Очраклы рәвештә, белештермичә. [*Айдар Сөмбелгә:*] *Менә, менә ачкычың. Абыең, онытып, кесәсенә салып килгән икән.* Д. Аппакова.

3. Икенче эш белән мавыгып, төп эштән читләшү, тукталу. *Дни мескен исә, сүземне ишеткәч, чәй ясавын онытып, гажәпләнеп, миңа күтәрелеп карады.* А. Шамов. *Шәмти абзый сүзне оста итеп матурлап сөйләүче бер кеше булганга, без, уенны онытып, аны тыңлап тора башладык.* М. Гали.

4. *күч.* Кимсетү, кайгыртмау, санга санамау. [*Вәли Хәсәновның*] *бар белгәне шул булды: байны баетты, ярлыны онытты.* Г. Ибраһимов. || Игътибарсыз калдыру. *Якуб Столяровка күтәрелеп карады: ул, газеталарына күмелеп, Якубны бөтенләй онытты, утыра да утыра.* И. Гази.

5. *күч.* „Үз-үзен“, „үзләрен“, яки „үзенең кайдалыгын“ кебек сүзләр янында нәрсәгә дә булса бик нык бирелү, бөтен барлыкны шул нәрсәгә юнәлтүне белдерә. *Зал тулы халык баягыча, үзләренең кайда утырганнарын онытып, сәхнәгә йотылганнар.* М. Әмир. *Миң шатлыгымнан үз-үземне, үземнең кайдалыгымны оныттым.* Ф. Әмирхан.

◇ **Онытканда бер** — бик сирәк. *Жил онытканда бер исеп куя.* Г. Гобәй. *Без, Иделне чыгып калага якынлашканда, яңгыр әкренәйде; онытканда бер генә әз-мәз сипкәләп ала иде.* Ак юл.

ОНЫТУЧАН *с.* Тиз онытучы, хәтере начар. *Онытучан кеше.*

ОНЫТУЧАНЛЫК *и.* Онытучан булу сыйфаты, хәле. *— Гафу ит, туганкай, ни әйтсәң дә шул әлеге минем таркаулык, онытучанлык.* Ш. Камал. *— Мондый онытучанлык дәвалаучы врачка гафу ителми.* Г. Әпсәләмов.

ОНЫТТЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* оныту. *— Шәрәфи абзый, сүзең онытмыйм, Красный-Слабудский өязендә бер генә дә юньле кеше юк, диләр бит, һәммәсе дә ат караклары ди!* Ш. Камал. || Юкка чыгару. *Иске могҗизаларның барысын да онытты инде фән сүзе.* М. Гафури. *Шул матур көлүләрең аның бар кебек мәшәкатьләрен онытты иде.* Дәрдмәнд.

2. *сөйл. юкл. һәм боеру форм.* **онытты́рма (гыз).** Искә төшерү, искәртүне сораганда әйтелә. *— Онытмагыз, — диде Добренцов, — мин сезгә бу сорауга җавап була алырлык бер китап бирермен.* Г. Минский. *— Иртәгә иртүк - - - Габбас картны күреп әйтергә онытмырма әле.* М. Фәйзи.

ОНЫТЧАК *с. диал. к.* онытучан. *Онытчак буркен югалтыр, куркак башын югалтыр.* Мәкаль. *Бар иде Казанда туфаннан калган бер хәзрәт. - - - Картлык сәбәпле, онытчак хәлгә төшкән бер бәндә.* И. Рәмиев.

ОНЫТЫЛМАС *с.* Онытырга ярамый торган, истәлекле; онытылуы мөмкин булмаган, һаман хәтердә саклана торган. *Онытылмас еллар. Онытылмас очрашу.* □ *„Минем беренче мәхәббәтем, онытылмас мәхәббәтем түгелме ул кыз?“ дип уйлап барды егет.* А. Әхмәт. *Бу минутлар аларның икесендә дә онытылмас минутлар булып калдылар.* А. Шамов. || Беркайчан да онытылмый торган. *Гомумән алганда, атаклы халык шагыйре Г. Тукайның онытылмас әсәрләре рәтенә кергән бу көчле поэмасын либретто итеп эшләү — бик дөрес һәм яхшы идея.* М. Җәлил.

ОНЫТЫЛМАСЛЫК *с. к.* онытылмас. *Күңелдә онытылмаслык әз калдыру.* □ *Ялгыз кабер калды яр буенда, Онытылмаслык данга уралып.* Ә. Исхак. *Син: „Галия... бу онытылмаслык кичәнең дәвам итүен телим“, — дип, мине кочагыңа алдың.* Г. Кутуй.

ОНЫТЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* оныту (1 — 3 мәгъ.). *Газинурның сөйләгән вакытта онытылган каушавы яңадан йөргән салкынайтты.* Г. Әпсәләмов. *Минем - - - онытылып калган кара тышлы дәфтәрне дә җибәрсәгез иде, зинһар.* Г. Тукай. *Син кем, Белмим, Әллә күптән инде Онытылган бер иске танышмы?* һ. Такташ. || *з-сыз форм.* Искә килмәү, хәтердән чыгу. *— Ирләр өйдә вакытта кислота алдырырга онытылган.* Г. Камал.

2. Тирә-якны, үз-үзеңне оныту; чынбарлыктан аерылу. *Йөри торгач, онытылып китә язганмын, ат җибәрер вакыт җиткән икән.* Ф. Хөсни. *— Сез музыканы бик яратасыз булырга кирәк, бөтенләй онытылгансыз.* Ф. Бурнаш. || Һуштан язу, аңны югалту. *Җәүдәтнең ул вакытта әле сөйләшерлек тә хәле юк, ул аңына килә дә, тагын бик озак онытылып ята.* Г. Бәширов. *Онытылган ул, тагын һушсыз тынган, Саташкан ул, газап кичергән.* Ш. Маннур.

3. Үз-үзеңне тота алмау, ихтыяр көчен югалту. *Сиражи, әлеге дә баягы, дигәндәй, бик кызу канлы кеше булгач, онытылып китеп, балтага сузыла.* Г. Минский. *Хәлим, онытылып, шулкадәр каты кычкырды, шактый читтә йоклап яткан малайларның берничәсе башларын күтәреп карадылар.* Г. Гобәй. || Кабул ителгән тәртипне бозу. *— Баганага бәйләп яндырылган иптәшләр күз алдына килеп басты. „Аркашка! Үч ал!“ дигән кебек булдылар: мин онытылдым. Нишлим?* Ә. Айдар.

4. *күч. рәв. мәгъ.* **онытылып.** Бик нык мавыгып, бирелеп. *Онытылып уку. Онытылып эшләү.* □ *Сандугач, һич туктый алмыйча, онытылып-бирелеп сайрый да сайрый.* Ш. Әхмәдиев. *Уйный-көлә бер кайгысыз, Онытылып сабыйларча.* Г. Хуҗи. || Бик тыныч һәм каты (йоклау турында). *Ул тәмам онытылып йоклады: төш тә күрмәде, саташмады да.* Ш. Еникеев.

ОНЫТЫЛУЛЫ *с.* Хафасыз, борчылусыз, бик тыныч. *Без - - - сугыштан соңгы беренче 2 — 3 көнне бөтенләй онытылулы ялда үткәрдек.* Ә. Айдар.

ОП: оп итү — егылу (балалар телендә).

ОПЕ'КА *и.* 1. Эшкә сәләтсез кешеләрне (балаларны, психик авыруларны, картларны) тәрбияләүне өскә алу, аларның шәхси һәм милек хокукларын кайгырту эше (дәүләт власте тарафыннан кемгә дә булса ышанып тапшырыла һәм контроль астында тотыла). || Икономик хәлсез кечкенә илнең яки колониаль территорияләрдәге халыкларның икономик һәм политик иминлеген тәэмин итүне өскә алу эше. [*Колониаль*] *территорияләрнең халыклары үз илләрен үзләре идарә итәргә сәләтсез дигән булып, бу илләр өстеннән Милләтләр Лигасы опекасы куелды, ә опеканы тормышка ашыру җиңүче илләргә тапшырылды.* Яңа тарих. || *күч.* Берәр кеше турында һәрвакыт (еш кына бәйләнчек) кайгырту, аның эшенә ярдәм итеп, юнәлеш биреп, күзәтеп тору хәле. *Тик бер нәрсә Таһирны бик куандыра иде: Мәрфуга Минвәлиева, ниһаять, Сарымсаковның опекасыннан котылды.* Г. Ахунов.

2. Шундый эш йөкләтелгән берничә кеше яки учреждение; опекуннар. *Таныш юрист белән сайләштем. Ул миңа моннан соң бу өйгә ялгыз килеш керепйөрмәскә, райисполкомның опека бүлеге инспекторы белән берлектә барырга киңәш бирде.* С. Баттал.

Опекага алу — кемне дә булса тәрбияләү, карау эшен үз өстеңә йөкләү.

ОПЕКУН *и.* 1. Опеканы (1 *мәгъ.*) үз өстенә алган кеше. *Миңа бу сәфәр никадәр читен булса да, һаман да, Казанга барып, опекун белән Газизә килә торган поездны көтәргә тугры килде.* Г. Тукай.

2. *күч.* Берәр кеше турында кайгыртучанлык күрсәтүче, аның эшенә ярдәм, юнәлеш биреп күзәтеп торучы кеше. *Кешеләр тел тидерә башлаган чакта да, [Шәйхи абзый] аны якларга тырышты, вак-төяк кимчелекләренә күзен йомды, кыскасы, егетнең опекунына әйләнде.* Ә. Еники.

ОПЕКУНЛЫК *и.* Опекун булу вазифасы. — *Кеше үзе теләми икән, опекунлыкны без көчләп тага алмыйбыз.* С. Баттал. || *с. мәгъ.* Опекун булу белән бәйләнешле. *Опекунлык хокуклары. Опекунлык эше.*

Опекунлык итү — 1) опекун булу, опекун вазифаларын башкару; 2) *күч.* берәр кеше турында кайгыртучанлык күрсәтү, үзенең шундый хезмәтен аңар көчләп тагу.

О'ПЕРА *и.* 1. Музыка һәм җыр белән генә башкарыла торган сәхнә әсәре. *Җырчылар студиянең соңгы елларында Н. Җиһановның оригиналь операларын „Качкын" һәм „Ирек" партияләре өстендә эшләделәр.* М. Җәлил. *Театр өчен язылган опера, балет һәм музыкаль комедия кебек синтетик әсәрләрдә музыканың роле тагын да зуррак.* Ж. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Опера уйнала торган. *Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры.* || *с. мәгъ. Операга мөнәсәбәте булган. Опера җырчысы.* || Сәхнәдә шундый әсәрне гәүдәләндерә торган театраль тамаша. *Кичә әле Мостафаны каплаган бу фикер тамырланып җитмәгән, опера тыңлау белән, вакытлыча таралып та торган иде.* Ф. Әмирхан. *Бара-бара* [*Зыя*] *концертларга да йөри башлады. Ниһаять, операларга чаклы барып иреште.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл.* Опера театры. *Без тагын шул ук Лувр, Опера мәйданнары тирәсендә.* Г. Гали. *Татар операсы илебездәге бөтен милләт халыкларының дуслыгы, туганлыгы, бердәмлеге нигезендә, шул туганлыкның чәчәк ату күренеше булып барлыкка килде.* М. Җәлил.

ОПЕРАТИ'ВКА *и. сөйл.* Производствода кичектергесез эшләрне хәл итү өчен үткәрелә торган кыска вакытлы киңәшмә.

ОПЕРАТИВ *с.* 1. Операциягә (2 мәгъ.) караган, операциягә бәйләнешле. — *Бу юлы мин командир буларак сөйләшәм. Шуңа күрә бу әйткәннәрне үтәү — закон. Әнчек үтәүнең оператив планын төзү — сезнең өстә.* Ш. Маннур. *Штаб начальнигы --- комендантны, оператив дежурныйларны кыздыра иде.* Каз. утл.

2. Нинди дә булса бурычларны турыдан-туры практик тормышка ашыру белән бәйләнгән. *Оператив эш планы.* □ [*Мин*] *Арча кантонының җинаятьчеләр эзләү бүлегенә оператив эшкә күчтем.* Г. Бәширов. *Шигырь — бик оператив, сугышчан жанр.* И. Гази.

3. Теге яки бу практик бурычларны дөрес һәм тиз тормышка ашырырга сәләтле. *Проблемасы яхшы. Тырышканда Булыр кебек. Ләкин ничегрәк?.. Оператив булса җитәкчелек, Контролебез яхшы куелса.* Ш. Мөдәррис.

ОПЕРАТИВЛЫК *и.* Оператив (3 мәгъ.) булу сыйфаты. *Эштә оперативлык җитмәү.* □ — *Синдә бер дә оперативлык юк! --- Синең һәрвакыт авызыңа чәйнәп салырга кирәк.* А. Расих.

ОПЕРА'ТОР *и.* 1. Катлаулы машина җиһазлары, җайланмалары белән идарә итүче квалификацияле эшче. — *Валеев мастерлар курсына китте. Нурееваны өлкән оператор итеп күтәрдек.* А. Әхмәт. *Нефть чыгаруда төп эшләр операторның беләк көченә, аның өлгерлегенә һәм тапкырлыгына тапшырылган иде.* Р. Төхфәтуллин.

2. Транспортта диспетчердан телефон аркылы боерыклар алып һәм аңа хәрәкәт турында белешмәләр биреп торучы хезмәткәр.

3. Кинога төшерү эшләрен башкаручы белгеч; кинооператор. *Кино аппаратлары эшли башлый. Оператор чаба-ашыга, Кул чабалар, алкыш уртасында Тугызынчы съезд ачыла.* Һ. Такташ. || Телевидениедә сурәт тапшыру эшләрен башкаручы белгеч. *Телевидение операторы.*

ОПЕРА'ЦИЯ *и. мед.* 1. Дәвалау максаты белән тән тукымаларына һәм әгъзаларына механик тәэсир ясау (яру, ямау, кисеп ташлау һ. б. ш.) эше. *Йөрәккә операция ясау.* □ *Алар клиникага кергәндә, операция бара иде инде.* Ш. Камал. *Нәсимә, төн буе лазаретта, Хәсән янында кизү торып, операциядән соң аның хәле яхшырганны күргәч, Кремльгә китте.* К. Нәҗми.

2. *хәрби.* Бердәм максат, бурыч белән берләшкән сугыш хәрәкәтләре җыелмасы яки шундый бер сугыш хәрәкәте. *Разия үзенең бу хатында авиадесант операцияләрендә катнашуын, бер „эш" өчен хәтта медаль дә алып өлгерүен язган.* И. Гази. — *Ватан сугышының башыннан бирле безнең полк иң каты операцияләрдә дә сынатмады һәм сынатмас дип ышанам мин.* Ф. Кәрим. || Бер максатка юнәлтелгән нинди дә булса чаралар, эш-хәрәкәт. [*Хәйдәрне*] *кулга алу операциясен Огурцов үзе башкарырга булды.* Г. Минский.

3. *махс.* Технологик процессның аерым стадиясе. *Станокта өч операцияне берьюлы башкару.* □ *Эшне нәкъ менә Ишняз һәм аның бригадасы башкара торган операция — стабилизатор канатлары тоткарлый иде.* Г. Әпсәләмов.

4. *махс.* Сәүдә яки финанс алыш-бирешләре. *Тышкы сәүдә операцияләре.* □ *Без тагын шул ук Лувр, Опера мәйданнары тирәсендә. Чөнки үзәк шунда. Чөнки Парижның 350 ләп банкысының зур операцияләре шунда.* Г. Гали.

ОПЕРА'ЦИЯЧЕ *и. махс.* Банкта операцияләр (4 мәгъ.) алып баручы хезмәткәр.

ОПЕРЕ'ТТА *и.* Җыр, бию һәм сөйләшү элементлары белән чиратлашып бара торган комедия характерындагы музыкаль сәхнә әсәре. *Бездә хәзер, композитор белән авторның берләшеп, бергә оперетта тудыру гадәтен тәэрибәгә кертергә кирәк.* М. Җәлил. *Гәрәй морза, мәшһүр опереттадагы җыр көенә сызгырынгалап, кырынып, чистарынып бетте.* М. Галәү.

О'ПИСЬ *и.* Исәпкә алына торган әйберләрнең (милек, документлар һ. б.) исемлеген төзү эше. [*Мулланың*] *өенә опись белән киләләр.* Э. Касыймов. — *Иптәш командир! Монда тәртип сакларга, әйберләргә опись ясарга берничә солдатыгызны калдырырга кирәк.* Т. Гыйззәт. || Исәпкә алынган әйберләр (милек, документлар һ. б.) теркәлгән исемлек. — *Син, Габдулла агай, опись кәгазенә кергән әйберләрне сатмаска тиешлесең һәм, сатмаячагыңны белдереп, монда кул куй.* Һ. Такташ.

ОП-ОЛЫ *с. Артык. дәр. к.* олы (1, 2 мәгъ.). *Ул үзен бала дип санаудан ерак, аның оп-олы кеше булып кылануы күзгә ташланып тора.* А. Расих.

ОПОЛЧЕ'НЕЦ *и.* Ополчение сугышчысы, ополчениедә хезмәт итүче. *Ополченецлар, Наполеонны җиңгәннән соң, өйгә кайткач, ирек бирелер дип өметләнгәннәр.* СССР тарихы.

ОПОЛЧЕ'НИЕ *и.* 1. Регуляр армиягә ярдәм итү өчен киң халык массасы иреклеләреннән төзелгән гаскәр. *Завод ишек алдында танклар, туплар тезелгән. Халык ополчениесеннән оештырылган артиллерия полкының командиры --- заводның директоры алдында полкның сугышка хәзер булуы турында рапорт бирә.* Х. Садрый. || *с. мәгъ.* Ополченецлардан төзелгән, ополченецлардан торган. *Ополчение отряды.* □ *Корал тотар хәле булганы, нәрсә бар шуның белән коралланып, ополчение батальоннарында сугышты.* Г. Гобәй.

2. Патша армиясендә хәрби хезмәттә булмаган яки яшь ягыннан запаска чыккан кешеләрдән төзел-

гән резерв. *Рус гаскәрләренең күп өлешен һаман әле системалы хәрби өйрәнү үтмәгән дворяннар ополчениесе тәшкил иткән.* СССР тарихы.

ОП-ОЧЛЫ *с. Артык. дәр. к.* очлы. *Аның --- ямьяшел күзләре кинәт ничектер оп-очлы булып, ялкынланып китте.* А. Шамов.

ОППОЗИЦИОН *с.* 1. Оппозициядә торган, оппозиция белдергән. *Оппозицион блок оештыру. Оппозицион партияләр. Оппозицион караш.*

2. Нәрсәгә дә булса каршы мөнәсәбәт яки берәр нәрсә белән килешмәүчәнлек белдерә торган. *Патша Россиясендә бу милли кысынкылыкларга каршы изелүче милләтләрнең укымышлылары арасында --- оппозицион хәрәкәт күтәрелде.* М. Җәлил.

ОППОЗИЦИОНЕР *и.* Оппозиция члены, тарафдары.

ОППОЗИЦИОНЛЫК *и.* Нәрсәгә дә булса каршы мөнәсәбәт, берәр нәрсә белән килешмәүчәнлек. *Революция үскән саен, буржуазия үзенең оппозиционлыгын югалта барды, --- һаман күбрәк дәрәҗәдә контрреволюция лагерена күчә барды.* КПСС тарихы.

ОППОЗИ'ЦИЯ *и.* 1. Каршы булу, каршылык күрсәтү хәле; үз карашларын, үз политикасын икенче бер карашларга, политикага каршы куючылык. *Демократик идеяләр белән сугарылган, помещиклар һәм буржуазия строена карата оппозициядә булган төркем язучыларның иҗат юллары бөтенләй башкача булды.* М. Җәлил.

2. Нинди дә булса берәр җәмгыять, оешма эчендә үз карашларын, политикасын күпчелекнең карашларына, политикасына каршы куючы партия яки группа. *Тагын минем гаепне ачып салдылар. --- Мин әйтәм, бичара йолкышны хәзерге оппозициядән дә начар хәлгә куялар, күрәсең, дим.* К. Нәҗми. *Съезд вакытына „хәрби оппозиция" дип аталган оппозиция барлыгы беленде. --- Оппозиция армиядә тимердәй дисциплина кертүгә, иске хәрби белгечләрнең тәҗрибәсеннән файдалануга каршы чыкты.* КПСС тарихы.

ОППОНЕНТ *и.* Бәхәстә, диспутта, диссертацияләр яклаганда кемнең дә булса фикерләренә, дәлилләренә каршы чыгып сөйләүче яки аның фикерләрен, дәлилләрен яклаучы (рәсми оппонент турында). — *Минемчә, сезнең эшегезнең үзәге юк, җаны юк. — Ансы инде сезнең эшегез түгел, Рәхим Миңлебаевич. Ул турыда --- оппонентлар әйтерләр.* А. Расих. || Гомумән бәхәстә каршы булган кеше, кемгә дә булса каршы төшүче. *Әле бер оппоненты, әле икенчесе иске исәп-хисапларны казып чыгара-чыгара тәгәрмәчкә таяк тыкты.* Г. Әпсәләмов.

ОППОНЕНТЛАУ *ф.* Диспутта, бәхәстә оппонент булу, оппонент булып чыгу.

ОППОРТУНИЗМ *и.* 1. Эшчеләр хәрәкәтендә һәм пролетар партияләрнең үз эчләрендә пролетариатның сыйнфый интересларын буржуазия интересларына буйсындыруны, сыйнфый көрәштән, социалистик революция һәм пролетариат диктатурасыннан баш тартуны пропагандалаучы, килешүчәнлек политикасын алга сөрүче, марксизм-ленинизмга дошман булган агым. *Оппортунизмга каршы көрәш — эшчеләр хәрәкәтенең закончалыгы ул.* КПСС тарихы.

2. Гомумән принципсызлык, шартларга җайлашучанлык, килешүчәнлек. *Ул әле һаман да үзенең нинди ялгыш юлга кереп киткәнен, нинди оппортунизм сазлыгына кереп батканын аңламый.* Ә. Еники.

ОППОРТУНИСТ *и.* 1. Оппортунизм (1 мәгъ.) политикасын тормышка ашыручы; оппортунизм тарафдары. — *Кантком күләмендә дә, үзебезнең волость оешмасы тирәсендә дә фаш ителмәгән кулак агентлары бар. Партия тоткан юлга каршы килүче оппортунистлар.* М. Әмир.

2. Принципсыз, шартларга җайлашучан, килешүчән, хыянәтчел кеше. — *Имеш, мин тормыштан калып барам, оппортунист, янәсе.* Р. Ишморат.

ОППОРТУНИ'СТИК *с.* Оппортунизмга бәйләнешле; оппортунистларга хас. *Партия үзен оппортунистик элементлардан тазарту белән ныкгый.* КПСС тарихы.

ОППОРТУНИСТЛАШУ *ф.* Оппортунистка әйләнү. *Меньшевикларның һаман оппортунистлаша барган линиясенең --- бик зур зарар китерүен исәпкә алып, В. И. Ленин, большевиклар бу линиягә каршы көрәшне көчәйттеләр.* КПСС тарихы.

ОППОРТУНИСТЛЫК 1. *с.* Оппортунизмга (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле, оппортунистларга (1 мәгъ.) хас. *Оппортунистлык теориясе. Оппортунистлык агымы.*

2. *и.* Оппортунистларга (2 мәгъ.) хас сыйфат. *Бу аның актив арасындагы оппортунистлык җәясен тартып караү маневры иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ОПРИ'ЧИНА, ОПРИ'ЧНИНА *и.* 1. Патша Иван Грозный тарафыннан бояр-князь оппозицияләрен тар-мар итү һәм үзәкләшкән Русь дәүләтен ныкыту өчен үткәрелгән гадәттән тыш чаралар системасы. *Опричнина еллары.* □ *Опричина элекке уделлардагы князь балалары — боярларның властен бетерә, аны бердәм патша власте белән алмаштыра.* СССР тарихы. || Дәүләтнең патша Иван Грозный идарәсенә буйсынган һәм бояр-князь оппозициясенә каршы көрәштә терәк булган өлеше. *Патша --- әкренләп илнең иң яхшы яртысын, бай шәһәрләр һәм сәүдә юлларын опричинага кертә.* СССР тарихы.

2. Иван Грозный режимында булдырылган хәрби полиция көчләре.

3. Борынгы Россиядә, князь үлгәч, аның хатынына гомер буе файдалануга бирелгән җир участогы.

ОПРИ'ЧНИК *и.* Опричнина гаскәрләрендә хезмәт итүче йомышлы дворян, сугышчы. *Опричникларның котырынуы чиктән ашып киткән. Алар боярларның мал-мөлкәтләрен комсызланып талыйлар, крестьяннарның атларын, сыерларын, икмәкләрен тартып алалар.* СССР тарихы.

ОПТА'ЦИЯ *и. махс.* Бер дәүләттән икенче дәүләт карамагына күчкән территориядә яшәүчеләргә бирелгән гражданлык сайлап алу хокукы.

ОПТА'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Оптация хокукы нигезендә үзеңә теге яки бу гражданлыкны сайлап алу.

О'ПТИК I *и.* 1. Оптика (1 мәгъ.) өлкәсендәге белгеч.

2. Оптик пыялалар, приборлар эшләүче оста.

О'ПТИК II *с.* 1. Оптикага (1 мәгъ.) караган; оптика (2 мәгъ.) кулланыга нигезләнгән. *Оптик күчәр. Оптик прицел.* □ [*Артиллериядә*] *оптик приборлар һәм югары математика белән эш итәргә кирәк* М. Җәлил.

2. Яктылыкка мөнәсәбәтле, яктылык тәэсирендә була торган. *Оптик күренешләр. Оптик сигнал. Оптик иллюзия.*

Оптик пыяла — оптик приборларда кулланыла торган кабарынкы яки батынкы пыяла; линза.

О'ПТИКА *и.* 1. Физика фәненең яктылык үзенчәлекләрен, яктылык күренешләренең закончалыкларын өйрәнә торган бүлеге. *Геометрик оптика. Физиологик оптика. Электроник оптика.* □ — *Монда утырыгыз, иң шәп күренә торган җир, оптика законнары буенча суйган да каплаган! — дип, урын тәкъдим итте миңа бер егет.* А. Тимергалин.

2. *җый.* Шул фәннең законнары нигезендә эшли торган прибор һәм кораллар. [*Бинокль линзасын шомарту кебек*] *вак һәм күз бетергеч эшне оптика заводларында махсус станоклар башкара торгандыр.* Каз. утл.

ОПТИМАЛЬ *с.* Иң уңай, кулай; нәрсәгә дә булса тулысынча ярый, туры килә торган. *Язгы чәчүнең оптималь сроклары.* || Мөмкин булган иң зур. *Оптималь план. Оптималь йөкләмәләр алу.*

ОПТИМИЗМ *и.* Тирә-юньгә күтәренке, көр күңелле мөнәсәбәт; тормышка, киләчәккә өмет, ышаныч белән карау, һәр нәрсәнең яхшы, уңай ягын күрергә тырышу халәте; *киресе:* пессимизм. *Идият үзенең оптимизмы белән пессимист начальникны бәреп екты.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Мансур әсәрләренә, барыннан да элек, гражданлык пафосы, оптимизм һәм гуманизм тойгылары хас иде.* Г. Хуҗиев.

ОПТИМИСТ *и.* Оптимистик рухлы, оптимизм белән сугарылган кеше; *киресе:* пессимист. *Утәсе юл әле аздан түгел, Атакалар саны билгесез. Мин оптимист үзем, ә шулай да, Сугыш бит ул булмый үлемсез.* З. Мансур. *Тынгысызлар, оптимистлар бер генә түгел, мең мәртәбә алданып та мең дә беренче очракка барырга көч табалганнар.* Р. Гатауллин. | *с. мәгъ. Рәфгать - - - бик күтәренке күңелле, оптимист егет булып чыкты.* М. Әмир.

ОПТИМИ'СТИК *с.* Оптимизм белән сугарылган, көр, күтәренке күңелле. *Бу арияда ул үз-үзен үтерергә карар кыла, ләкин, акылына килеп, арияне бик оптимистик рухта, дәртләнеп, көр күңел белән тәмамлый.* М. Җәлил. *Повестьның гомуми пафосы һичшиксез оптимистик.* Сов. әд.

ОПТИМИСТЛАНУ *ф.* Оптимист кешегә әйләнү. *Казанга апрель башларсыз кайтмаска торам. - - - Монда бөтенләй оптимистландым ахры.* Г. Тукай.

ОПТИМИСТЛА'РЧА *рәв.* Оптимистларга хас булганча. *Тормышка оптимистларча караш.*

ОПТИМИСТЛЫК *и.* Оптимист булу сыйфаты. [*Кариевның*] *оптимистлыгы башкаларга да йогынтысыз калмады.* И. Рәмиев.

ОПТЫ *и.* Карплар семьялыгыннан төче суларда яши торган балык; *русчасы:* язь. *Балык чиртмәде, балык капмады. Хәер, көмеш чабакларның, ялкау оптыларның кирәге юк иде аларга.* Г. Мөхәммәтшин.

ОПТЫМ *рәв. сөйл.* 1. Зур партияләр белән, күпләп; күмәртәләп. *Оптым сатып җибәрү.*

2. Тулысынча, берьюлы. *Өмәгә оптым күтәрелеп чыгу.*

◊ **Оптым илә́йһи** — барысын берьюлы, барысын берраттән.

ОРА'КУЛ *и.* 1. Борынгы Грециядә һәм Римда берәр сорау белән мөрәҗәгать иткән кешеләргә алла исеменнән киләчәк турында хәбәр биреп торучы илаһи зат, җрец. *Кабилә башлыгы белән берраттән бездә дини идеология, культ башлыгы, күрәзәче, багучы, башкаларда җрец, оракул кебекләр килеп чыккан.* Н. Исәнбәт. *Көннәрдән беркөн, ни сәбәптәндер, оракул саташкан: бер мәслихәтче килсә, яңлыш мәслихәт бирә, икенче берсенә ап-ачык ялганлый.* Г. Тукай. || Киләчәк турында алдан хәбәр биреп тора торган урын, храм. *Урта Грециядә Дельфах шәһәрендәге оракул бигрәк тә атаклы булган.* Бор. зам. тарихы.

2. *күч. кит.* Бөтен фикерләре, әйткән сүзләре кире кагылмаслык хакыйкать, яңалык дип санала торган кеше.

ОРАН *и. иск.* Яуга чакыру авазы.

◊ **Оран салу** — 1) шатлык хисе белдереп яки әйдәп кычкыру. *Ә Салават чорлар үре аша Оран сала: — Дсәй, мин тере!* Х. Туфан; 2) *к.* сөрән салу 2.

ОРАНГУТАНГ *и. зоол.* Суматра һәм Борнео утрауларында яши торган кешесыман зур маймыл. *Орангутанг — малайлылар телендә урман кешесе дигән сүз.* Зоология. •

ОРАНЖЕРЕЯ *и.* Көньяк үсемлекләре үстерү һәм кышлату яки елның теләсә кайсы вакытында җимеш, яшелчә, чәчәкләр үстерү өчен пыялалап әшләнгән махсус корылма; теплица. *Менә Берлинны чәчәк белән тәэмин итүче оранжереялар башлана.* Г. Гали. *Кунаклар - - - матур оранжереяга охшаган, күз явын алырлык чәчәкләр, мәңге яшел үсемлекләр белән бизәлгән якты коридорларда озак-озак сөйләшеп йөрделәр.* Г. Әпсәләмов.

ОРА'ТОР *и.* Халык алдына чыгып речь сөйләүче кеше. *Анда ораторлар сөйли, Монда пионерлар: — Ул үлмәде, Ленин Мәңге бар!* Һ. Такташ. *Оратор үзенең урынсыз сүзләре белән крестьяннарның иң авыртканн җирләренә кагылды һәм халыкның гөж итеп ярсып китүенә сәбәп булды.* И. Гази. || Оста сөйләү сәләтенә ия булган кеше. *Госман сүзгә ашыкмады. - - - Оратор булмаганга, туп-туры гына әйтте дә куйды.* Г. Ибраһимов.

ОРАТО'РИЯ *и.* Драматик сюжетка язылып, хор, җырчы һәм оркестр тарафыннан башкарыла торган зур музыкаль әсәр. *Җ. Фәйзи Такташның „Киләчәккә хатлар" поэмасына кантата яки оратория язарга җыена.* Каз. утл.

ОРА'ТОРЛАРЧА *рәв.* Ораторларга хас булганча; ораторлар кебек оста, матур итеп.

ОРА'ТОРЛЫК *и.* Халык алдында речьләр сөйләү. *Ораторлыкка дисәң, шәһәрдә митингларда аңа каршы чыгучылар юк иде.* Ш. Усманов. [*Садыйкның*] *ораторлыктан тамагы карлыга, ашарга, эчәргә вакыты булмый.* Г. Ибраһимов.

◊ **Ораторлык итү** — 1) халык алдында речь сөйләү, речь белән чыгу. *Алар арасында - - - маевкада ораторлык иткән Мифтахетдин бабай да бар иде.* А. Расих; 2) *ирон.* оста теллеләнеп, нәрсә турында да булса бик кызып, озын итеп сөйләү. *Ул да түгел, ТКУ дан үзләрен тәмам пешеп чыккан яшь марксистлар итеп санаучы, туры килсә, авызларыннан төкерекләр чәчә-чәчә ораторлык итүче - - - Яуми, Ф. Мөсәгыйть, Г. Кадиров килеп чыга.* Ф. Хөсни. **Ораторлыкка тотыну** *сөйл., ирон. — к.* ораторлык итү (2 мәгъ.). *Госман - - - ялкынланып, бөтен гәүдәсе белән дулкынланып-дулкынланып ораторлыкка тотына.* Г. Ибраһимов.

ОРБИ'ТА *и.* 1. *астр.* Күк җисемнәренең, Җирнең ясалма иярченнәренең, планетаара станцияләрнең һ. б. ш. хәрәкәт итү юлы. *Ай орбитасы. Космик корабльне Җир әйләнәсе орбитасына чыгару.* □ [*Сәяхәтчеләр*] *корабны бик авырлык белән генә якындагы йолдыз тирәли орбитага чыгардылар.* А. Тимергалин.

2. *күч.* Кем яки нәрсәнең эшчәнлек яки хәрәкәт, таралыш өлкәсе, чиге, сферасы. *Кая гына җибәрсә дә язмыш, Этәрсә дә адәм баласын, Әйтерсең лә, түгры юлдан аны, Орбитадан сөрә аласың.* Х. Туфан.

ОРБИТАЛЬ *с.* Орбита буенча башкарыла торган. *Орбиталь очыш.* || Орбита буенча хәрәкәт итә торган яки хәрәкәт итү өчен билгеләнгән; нинди дә булса орбитада булган. *Орбиталь ракета. Орбиталь станция.*

О'РГАН *и.* 1. Билгеле бер идарә итү системасы булган дәүләт яки җәмәгать оешмасы. *Сайлау органнары. Тикшерү органнары. Мәгариф органы.* □ *— Дәүләт власте Эшче һәм Солдат Депутатларының Петроград Советы органы һәм Петроград пролетариаты гарнизонының башында торучы Хәрби Революцион Комитет кулына күчте.* Т. Гыйззәт.

2. Нинди дә булса партия, оешма, учреждение тарафыннан чыгарылып, аның карашларын һәм эшчәнлеген чагылдыра торган вакытлы басма. *Г. Камал [газетаны] татарлар арасында искелеккә каршы көрәш һәм демократик идеяләр таратучы бер органга әйләндерергә тырыша.* М. Гали.

ОРГА'Н *и.* Агач һәм металл трубалар тезмәсеннән торган тынлы, клавишлы бик зур музыка коралы. *Валерия мине консерваториягә орган музыкасы тыңларга чакырган иде.* Каз. утл. || Гомумән һәртөрле автоматик тынлы музыка коралларының атамасы. *Мин байлар йорт эченең матурлыгын, идәннән түшәмгә кадәр зур көзгеләрен, --- сандык кадәр зур органнарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.* Г. Тукай. *Зур күләм орган-оркестр уены ул елларда „Болгар", „Амур", „Сарай" --- ашханә-чәйханәләре залында уйнатылды.* И. Рәмиев.

ОРГАНИЗМ *и.* **1.** Мөстәкыйль яшәү, үсү, үрчү сәләтенә ия булган теләсә нинди тереклек иясе. *Иң файдалы даруларның да кайбер организмнарга тиешле тәэсирне бирә алмаганын врачлар бик күптәннән әйтеп киләләр.* Ш. Камал. *Кызлар аратирә үзара шулай тере организм өчен нинди матдәләрнең кирәклеге --- кебек „гыйлем" сүзләр сөйләшеп утырган чакта, Нургалигә, мыек очын тешләп, колак салып утырырга туры килә.* Ә. Еники. || Кешенең, җан иясенең физик яки психофизик үзлекләр җыелмасы. *Бала яраланмаган, ач кына. Аның хәле бик начардан түгел, организмы да көрәшкә сәләтлерәк, ә әнисе ашыгыч ярдәмгә мохтаж.* Г. Гобәй. [*Хәсәннең*] *таза, чыныккан организмы теләсә нинди авырлыкларга да риза.* А. Расих.

2. *күч.* Үзара органик бәйләнешле кисәкләрдән торган катлаулы бердәмлек. *Шәһәр — ул үзенә күрә бер организм.* Сов. әд.

ОРГА'НИК *с.* **1.** Хайван һәм үсемлек организмнары таркалу нәтиҗәсендә барлыкка килгән. *Органик калдыклар. Органик ашламалар.*

2. Составында углерод булган. *Органик матдәләр. Органик кушылмалар.*

3. *күч.* Нәрсәнең дә булса асылына, нигезенә кагылышлы; эчке, табигый. *Теория белән практика арасында органик бәйләнеш булдыру.* □ *Әдәби югары сыйфатлы либретто — операның органик кисәкләреннән берсе.* М. Җәлил. || *рәв. мәгъ.* Табигый рәвештә. *Хатын-кыз язмышы бездә, көннән-көн ныграк булып, гражданлык язмышы белән органик үрелә бара.* Ф. Хөсни.

□ **Органик химия** — химиянең углерод белән башка элементлардан торган кушылмаларны өйрәнә торган бүлеге.

ОРГАНЧЫ *и.* Органда уйнаучы музыкант. *Урамнан солдатлар музыка уйнап китәме, --- органчы [ишек алдына] кереп „Камаринский" уйнатамы, — әлек халык „ләхәүлә"не укымый тыңламыйдыр иде.* Г. Газиз.

О'РГИЯ *и.* **1.** Борынгы Грециядә: аракы һәм күңел ачу алласы Дионискә багышланган бәйрәм тантанасы.

2. *күч.* Үтә шау-шулы әчү — күңел ачу мәҗлесе.

ОРДА *и.* **1.** *тар. к.* урда.

2. Күпсанлы, ерткычларча басып керүче дошман гаскәре. *Ерткыч фашист ордалары бөек Идел капкасы төбенә килеп туктаган.* Ә. Маликов.

О'РДЕН I *и.* Сугышта яки эштә күрсәткән зур батырлыклар яки хезмәтләр өчен бирелә торган махсус билге. *Хезмәт Кызыл Байрак ордены.* □ *СССР Үзәк Башкарма Комитеты карары буенча „Кызыл йолдыз" колхозына Ленин ордены бирелгән.* К. Тинчурин. *Рәхимов --- күкрәгенә бер Кызыл Йолдыз, ике Дан ордены, берничә медаль һәм яралану билгеләре таккан.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Орденга мөнәсәбәте булган, орденга бәйләнешле. *Коридорда Муса Илтуганов күренә. Күкрәгендә, кат-кат булып, орден тасмалары тезелгән.* Д. Аппакова.

О'РДЕН II *и.* Урта гасырларда монахларның, руханиларның яки рыцарьларның билгеле бер устав нигезендә төзелгән оешмасы (общинасы). *Иезуитлар ордены.*

О'РДЕНЛЫ *с.* Орден белән бүләкләнгән. *Орденлы Татарстан. Орденлы язучы.* □ *Мин аны сугышның беренче көненнән үк беләм. Ул дивизиядә сугышка чаклы үк комиссар, орденлы.* Х. Мөҗәй.

О'РДЕР *и.* Язма күрсәтмә, боерык; берәр нәрсә бирү яки алу өчен рәсми документ. *Гәрәйнең квартира алуына бер атна. Кулына ордер алуга үк, әтиләренә телеграмма сукты.* А. Гыйләҗев. *Каюм --- һидияткә бер кәгазь кисәге сузды: — Менә, шәһәр советыннан [Садыйк бай водокачкасын коммунага алырга] бирелгән ордер.* Ш. Камал.

ОРДИНАР I. *и. геол.* Нинди дә булса сулыкта суның озак еллар күзәтелгән уртача күтәрелү дәрәҗәсе (тирәнлеге).

ОРДИНАР II *с. иск.* Штаттагы, штат буенча билгеләнгән. [*Хөсәен Ямашев*] *заманасының танылган профессор-галимнәре кул астында больницаларда ординар врач булып эшләде.* И. Рәмиев.

ОРДИНА'РЕЦ *и.* Командир янында яки штабта йомышлар үтәүче гаскәри хезмәткәр. *Полк командирының ординарецлары әледән-әле, колонна буеннан атларын камчылап, командирның приказын кычкырып үтәләр.* Г. Бәширов.

ОРДИНА'ТА *и. мат.* Пространстводагы ноктаның торышын билгели торган өч координатның берсе. *Ординатаны күчәре.*

ОРДИНА'ТОР *и.* Дәвалау учреждениесенең (больница, клиниканың) врачы; гадәттә ул аерым палата белән җитәкчелек итә, шунда тикшеренү һәм дәвалау эшләре алып бара. *Хәрби госпиталь ординаторы.* □ *Башта без врачлар, ординаторлар, --- санитарлар һәм эчке саклык өчен куелган кызылармеецларның исемлеген тикшердек.* Х. Садрый.

ОРДИНАТУ'РА *и.* **1.** Медицина буенча практик аспирантура. *Институтны тәмамлар алдыннан профессор дбүзәр Таһиров Гөлшаһидәгә ординатурада калырга тәкъдим итте.* Г. Әпсәләмов.

2. Ординатор вазифасы.

ОРДЫ (М)-БӘРДЕ (М) *рәв.* **1.** Ашыгып, кабаланып, дуамалланып. *Ул --- әйберләрен тарантаска ордыбәрдем төйи башлады.* Г. Гобәй. *Завод кечкенә түгел. Ордым-бәрдем генә салып булмый аны.* Г. Ахунов. || *с. мәгъ.* Ашыгучан, кабаланучан; дуамал. *Ордыбәрде идең син, Хабул, Нишләп хәзер шундый түгел син, ә?* Х. Туфан.

2. Күңел бирмичә генә, ничек әләкте шулай, ашыкпошык, өстән-өстән генә. *Монтажчылар арасында әле халтура яратучылар очраштыргалый — ордым-бәрдем генә эшләп бирәләр.* И. Гази.—*Тәнзиләнең ордыбәрде генә эшләп йөрүе турында мин күптән тукып килдем инде, әткәй.* Ф. Яруллин.

3. *күч.* Әдәпсез, тупас рәвештә. *Хатын-кыз белән --- орды-бәрде генә сөйләшмиләр аны.* М. Хәсәнов. | *хәб. функ.* [*Исмәтнең*] *сөйләшүе тупас, күбрәк ордым-бәрдем иде.* Г. Әпсәләмов.

ОРДЫРЫП-БӘРДЕРЕП *рәв.* Каты орынып, сугылып, бәрелеп. *Казаклар аның саен атлары белән кешеләрне ордырып-бәрдереп кысрыкладылар.* Г. Минский.

ОРЕОЛ *и. кит.* Данга, хөрмәткә күмелгәнлек. *Бу романтик герой, --- үз заманы кешеләре белән бергә, җиңүчеләр ореолының нурлары эчендә киләчәккә табан ашкынып атлый.* Г. Халит.

ОРИГИНАЛ *и.* Күчерү, яңадан бастыру өчен хезмәт иткән нәрсә; төп нөсхә. [*Язуны*] *укыгач та,*

Сәлахның беренче омтылышы аны ертып ташлау иде.— Ертмагыз, бу фәкать фотокопиясе. Оригиналы ышанычлы җирдә, — диде Юматша. Г. Әпсәләмов. *Документларның оригиналларын алдым да [Розаларга] юнәлдем.* С. Баттал. || Икенче телгә тәржемә итү өчен хезмәт иткән төп текст. *Оригиналы ничектер, әмма [мәкаләнең] русчасы шактый шома һәм үткен чыккан.* Э. Касыймов. *Шигырьнең оригиналына караганда артык 28 тезмәне әченә алуы Тукайның биредә дә коры күчерүче генә булмавын күрсәтә.* Г. Нигъмәти.

ОРИГИНАЛЬ *с.* 1. Төп, оригинал булган. *Оригиналь экземпляр.*

2. Мөстәкыйль иҗат нәтиҗәсендә туган, барлыкка килгән; ияреп эшләнмәгән, беркаян да алынмаган, тәрҗемә ителмәгән. *Туфан стиль, сурәтләү чаралары ягыннан да татар поэзиясендә бөтенләй оригиналь, үзенчәлекле юл ачты.* Х. Госман. *Г. Камал тәрҗемәчелек эшенә оригиналь әсәрләр яза башлау белән бер үк вакытта керешә.* М. Гали.

3. Башкаларга охшамаган, иярүчәнлектән азат булган; үзенә бертөрле. *Оригиналь шагыйрь.* □ *— Сезнең фикер йөртүегез бик-бик оригиналь. Хәтта, мин әйтер идем, зур игътибарга лаеклы.* А. Расих. || Гадәти булмаган, үзенчәлекле. *Гади кешеләр арасында шактый үзенчәлекле, оригиналь, кызыклы шәхесләр очрый иде.* И. Рәмиев. *Аның шулай оригиналь-рәк сүзләр куллану гадәте бар.* Г. Минский.

ОРИГИНАЛЬЛЕК *и.* 1. Төп нөсхә, оригинал (1 мәгъ.) булу сыйфаты. *Кулъязманың оригинальлеген раслау.*

2. Оригиналь (2, 3 мәгъ.) булу сыйфаты. *Дсәрне сәхнәгә куючы режиссер К. Тумашева һәм атказанган артист Х. Уразиковның эшендә оригинальлек һәм күңелле гадилек сизелә.* М. Җәлил. *Дүрт юл шигырьдә дүрт нәрсә турында сөйлиләр. Бу оригинальлек түгел, тәкъдибәсезлек.* Һ. Такташ.

ОРИЕНТАЛИСТ *и.* Көнчыгыш илләр тарихы, телләре һәм культурасы белгече. *Әйтергә кирәк, Мәржани эшчәнлегенең гыйльми әһәмиятен иң элек рус ориенталистлары бәяләделәр.* М. Госманов.

ОРИЕНТАЛИ'СТИКА *и.* Көнчыгыш илләрнең тарихын, телләрен, культурасын өйрәнә торган фәннәр җыелмасы.

ОРИЕНТА'ЦИЯ *и.* 1. *к.* ориентлашу.

2. Фәнни, иҗтимагый һ. б. ш. эшләрдә билгеле бер юнәлеш, кемгә яки нәрсәгә дә булса тотылган исәп. *Хәрәкәткә килгән җирле милли буржуазия үзенең төп политикасында --- госманлы төрекләренең әдәби теленә ориентация тотуның да реаль нәтиҗә бирмәгәнлегенә төшенә башлады.* Г. Халит.

3. *күч.* Нинди дә булса мәсьәләләрне, тирә-як хәлләрне ачыклауга, аңлауга юнәлтелгән эшчәнлек сәләте. *Укучы басманың азагында --- татар совет әдәбияты буенча фәнни хезмәтләр библиографиясе һәм исемнәр күрсәткече белән таныша ала. Алар фәнни материалны иңләүдә укучының ориентациясен җиңеләйтәләр.* А. Сайганов.

ОРИЕНТА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Горизонт якларына мөнәсәбәттә хәрәкәткә тиешле юнәлеш бирү (карта, компас һ. б. приборлар ярдәмендә). *„Союз-3" кораблен орбитадан идарә итеп төшерү өчен кирәкле юнәлештә ориентацияләү үткәрелде.* Соц. Тат.

2. *күч.* Кем яки нәрсә алдына билгеле бер максат, бурыч кую; киләчәк эшчәнлек өчен юнәлеш билгеләү, күрсәтү. *Академия театрыбыз әле драматургларны идея йөкләмәсе җиңел булган, күбрәк кассага хезмәт итә торган әсәрләр язуга ориентацияли.* М. Әмир.

ОРИЕНТИР *и.* Урында хәрәкәт юнәлешен билгеләргә, кирәкле җирне тиз табарга ярдәм итә торган билгеле бер предмет. *Бу яндырылган танкларның да ярдәме тиде: хәлиткеч һөҗүмгә күчкәнче, алар ориентир булып хезмәт итте.* Каз. утл. — *Иптәш командир, ориентир бер, ике бармак уңдарак, илле метр бирерәк ике кеше күрәм.* Г. Әпсәләмов.

ОРИЕНТЛАШУ *ф.* Горизонт якларына һәм әйләнә-тирәдәге урынга мөнәсәбәттә үзеңнең торган җиреңне билгеләү, тиешле юнәлеш ала белү. *Ориентлашу ярышлары.*

ОРКЕСТР *и.* 1. Музыка кораллары ансамбле. *Симфоник оркестр. Кыллы музыка кораллары оркестры. Тынлы оркестр.* □ *Залда ут сүнеп, дирижер үзенең таягын селкеп җибәрү белән, без оркестрның тавышлары аша әсәр әченә кереп китәбез.* М. Җәлил. *Оркестрлар җиңү маршын яңгыраталар.* А. Алиш. || Төрле уен кораллары белән бергәләп музыка әсәре башкаручы музыкантлар коллективы. *Сул очта баскан оркестрның җиз бырлыларында кичке шәфәкъ-нең алсу нурлары чагыла.* Г. Минский. *Иң алда — оркестр, оркестр каршында дирижер.* И. Гази.

2. Сәхнә алдында оркестр урнаша торган урын.

ОРКЕСТРАНТ *и.* Оркестрда уйнаучы музыкант. *Колхоз оркестрантлары.* □ *Арырак, оркестрантлар — баянчы, барабанчы, саксофон һәм флейтачылар уен коралларын төрле тавышка көйләп маташалар иде.* Г. Ахунов. *Бер секундта аның күз алдыннан халык белән шыгрым тулы тамаша залы, аның әсәрен башкарырга әзерләнүче оркестрантлар уза.* Каз. утл.

ОРКЕ'СТРЛАШТЫРУ *ф. махс.* Нинди дә булса музыкаль әсәрне оркестрда уйнау өчен эшкәртү, яраклаштыру. *Композиторның татар халык көйләренә нигезләп язылган икенче симфониясе бик оста оркестрлаштырылган.* Соц. Тат.

ОРЛЫК *и.* 1. Үсемлекнең яралгы һәм тышчадан торган җимеш бөртеге; үрчем башлангычы. *Орлык тартмачыгы.* □ *— Әти! Мин алмамны ашадым. Әчендәге орлыкларын җыеп куйдым.* Дәрдмәнд. *Исәр җил төрле үсемлекләрнең орлыкларын, куып, һәр җиргә тарата.* Г. Тукай. *Алабута орлыгы булганчы, солының саламы бул.* Мәкаль.

2. Үсемлекләрнең, ашлыкларның чәчү өчен махсус хәзерләнгән вак җимешләре, бөртекләре. *Чәчүлек орлыклары. Орлыклар тишелеп чыгу.* □ *Орлыгыңа күрә уңышы.* Мәкаль. *Алат базарына барып Бодай алдым орлыкка.* Җыр. *Хатын-кызлар кайсы орлык утыртып, кайсы сөзгечле чиләкләр белән түтәлләргә су сибеп мәш килә иделәр.* Ш. Камал. || Үсемлекнең утырту, чәчү өчен билгеләнгән кисәкләре (бүлбе, суганча һ. б.). *Орлык суган утырту.* □ *— Кәҗәмне сатып, әллә орлык бәрәңгесе юнәтерменме дигәнием.* Г. Бәширов. || *күч.* Берәр төрле эш, хезмәтнең башлангычы турында. *Революциянең яшь көчләре, көннән-көн күбәеп, алмаш сафларны тутыра баралар. Чәчкән орлыкларыңны алар тирес астында калдырмаслар.* Г. Нигъмәти.

3. *күч.* Нәрсәнең дә булса чыганагы, башлангычы; берәр күренешнең, хәлнең сәбәбе. *Киңәш — эшнең орлыгы.* Мәкаль. — *Мин монда җитди фәнни тикшеренү өчен матур орлыклар күрәм.* Г. Әпсәләмов. || Нинди дә булса эш-хәлгә этәрә торган башлангыч турында. *Һәрбер кыз үзенең сөйгәне алдында, барлык егетләр каршында да һичкемнән ким булып күренмәскә, күңелләрне ауларга, йөрәкләргә мәхәббәт орлыклары чәчеп үтәргә телә.* Г. Ибраһимов. *Чәчик җир йөзендә чын азатлык, чын туганлык, дуслык орлыгын.* М. Гафури.

4. *физиол.* Ирләрнең җенес бизләре эшләп чыгара торган сыеклык, җенес күзәнәкләре.

5. Нәсел; токым. *Күрше алпавытның җирен, урманын басып ал, йортын яндыр, үзен утка сал, тавышы да чыкмасын, токымы, орлыгы калмасын!* Г. Ибраһимов. *Эти, - - - чаптар бияне сатып, аның урынына, орлыгы калса ярар, кечкенә тамак булыр дип, икенче яшькә чыгып кына калган кырыкмыш тай алып калдырган иде.* М. Гали.

6. *сөйл.* Киндер орлыгы. *Орлык кәлҗемәсе.*

Орлык бөресе *бот.* — *к.* орлыкбөре. **Орлык йомыркасы (күкәе)** — бик кечкенә йомырка (тавыкныкы). **Орлык күбәләге** — игеннәргә зарар китерә торган кечкенә корткыч күбәләк; *русчасы:* огневка зерновая. **Орлык мае** — киндер орлыгыннан алынган май. **Орлык оны** — киндер орлыгын төеп ясалган яшькелт он (шул килеш тә ашыйлар, кәлҗемәсен дә пешерәләр). **Орлык суган** — орлыктан үскән төпле яшь суган. **Орлык яргыч** — орлык яру механизмы. **Орлык яру** — иген бөртекләрен кылчыгыннан, кабыгыннан арындыру, чистарту. **Орлык өлеше** *бот.* — орлыкта яфрак яралгысы. **Орлыксыз үрчү** *бот.* — җенессез, вегетатив юл белән үрчү.

◇ **Орлыгы Бохарада түгел** — табып, булдырып, эшләп була мәгънәсендә әйтелә. *Һи, күр, ниләр үсми дөньяда! Бохарада түгел орлыгы, Безнең җирдә үсә, Болгарда.* Н. Исәнбәт. **Орлык тергезү** — орлык хәстәрләп, шуны чәчеп, чәчүлек хасил итү, үрчетү.

ОРЛЫКБӨРЕ *и. бот.* Орлыкның яралгысы. *Чыршы да, нарат кебек, җил ярдәмендә читтән серкәләнә. Орлыкбөреләр күркәнең орлык кабырчыкларында ачык килеш урнашалар.* Ботаника.

ОРЛЫКЛАНДЫРУ *ф.* Үрчем алу өчен, ана хайванның җенси күзәнәкләрен ата хайванның җенси күзәнәкләре белән ясалма рәвештә кушылдыру, аталандыру. *Кәрим ага, ясалма орлыкландыру кертеп, 100 баш сарыктан 185 бәрән алуга иреште.* Каз. утл.

ОРЛЫКЛАНУ *ф.* 1. Орлык (1 мәгъ.) хәленә килү; орлык, җим барлыкка килү. *Бодай башлары орлыклану.* □ *[Киндерне,] тишелеп чыгу белән, казлар килеп йолкыйлар, - - - орлыкланy белән чыпчыклар килеп маен эчәләр.* Г. Галиев.

2. *к.* аталану. *Кәрәкәләр еш кына башка балыклар — сазан, кара балык, алтын карп сөте белән орлыкланып үрчиләр.* Соц. Тат.

ОРЛЫКЛЫК *и.* 1. Үсемлекнең орлык үсә, барлыкка килә торган оясы.

2. *к.* орлык 2. *Орлыклык өчен уҗым культураларын чиста парга гына чәчәргә кирәк.* Соц. Тат. || *с. мәгъ.* Орлык өчен билгеләнгән. *Орлыклык бәрәңге. Орлыклык суган.*

3. Ата җенес бизләре.

ОРЛЫКЧА *и.* Көнбагыш, күкбаш кебек үсемлекләрдә үзлегеннән ачылмый торган каты тышчалы җимеш. *Орлыкчадагы кебек, чикләвекнең дә җимеш тышчасы орлыкка тоташып үсми, ләкин чикләвек кабыгы агаччыл булуы белән орлыкчадан аерыла.* Ботаника.

ОРЛЫКЧЫЛЫК *и.* Орлык өчен үсемлекләр үстерү һәм сортлы орлыклар җитештерү белән шөгыльләнә торган авыл хуҗалыгы тармагы. *Орлыкчылык белгече.* □ *Орлыкчылык калалары булып, Күтәрелә гигант совхозлар.* Ә. Исхак.

ОРНА'МЕНТ *и.* 1. Кабатланучы геометрик элементларга яки үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына бәйләнешле мотивларга нигезләнгән төрле формадагы график һәм скульптур бизәкләр. *Халкыбызның бай орнамент сәнгате бар.* Н. Фәттах. *Колонналы йорт фасады, Орнамент ясый егет.* З. Мансур.

2. *муз. к.* орнаментика 3.

ОРНАМЕНТАЛЬ *с.* 1. Орнамент тәшкил иткән, орнамент характерындагы. *Татар халык сәнгатенә хас төсләр яратучанлык, буяуларга байлык асалы тукымаларда бөтен тулылыгы белән чагыла. Композициясе бик килешле төзелә, гадәттә берничә орнаменталь буйдан тора.* Каз. утл.

2. *күч. кит.* Купшы, артык чуар. *Орнаменталь стиль. Орнаменталь әсәр.*

ОРНАМЕНТА'ЦИЯ *и.* Орнаментның характеры; нинди дә булса архитектура стилендә, сәнгать әсәрендә орнамент элементлары җыелмасы.

ОРНАМЕ'НТИКА *и.* 1. Орнамент төшерү, орнаментлау сәнгате. *Орнаментика остасы.*

2. *к.* орнаментация. *Татар ювелирлык сәнгатенең орнаментикасына хас яфрак сыман бу бизәкләр Болгар сәнгатенең бөтен төрләрендә дә бик киң кулланылган.* Каз. утл.

3. *муз.* Көйне музыкаль бизәкләргә баета торган авазлар җыелмасы.

ОРНАМЕНТЛАУ *ф.* Орнамент төшерү, орнаменталь бизәкләр ясау.

ОРНАМЕНТЛАШТЫРУ *ф. к.* орнаментлау. *Өйнең эчке бүлмәләрендәге бөтен ишекләр, орнаментлаштырылып, көрән төстәге имәннән эшләнгән.* Ш. Камал.

ОРНАМЕНТЛЫ *с. к.* орнаменталь.

ОРНАМЕНТЧЫ *и.* Орнаментлар ясаучы оста. *Орнаментчылар бригадасы.*

ОРНИТО'ЛОГ *и.* Орнитология буенча белгеч, галим.

ОРНИТОЛО'ГИК *с.* Орнитологиягә караган, орнитологиягә бәйләнешле. *Орнитологик күзәтүләр.*

Орнитологик фауна — билгеле бер территориядә яши торган яки җир тарихының билгеле бер дәверендә яшәгән кошлар төркеме, җыелмасы.

ОРНИТОЛО'ГИЯ *и.* Зоологиянең кошларны өйрәнә торган бүлеге.

ОРОЧ *и.* Хабаровск краеның көньяк өлешендә яшәүче халыкның атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Кәрим Идел егете, ә Савушка биредә, Ерак Көнчыгышта туган, шунда үскән ороч малае.* Г. Әпсәләмов.

ОРТОДОКС *и. кит.* Ортодоксаль карашлы кеше. *Ренегатмы чыгыш ягыннан, Ортодоксмы ул, мәсәлән?!* Каз. утл. || *с. мәгъ.* Ортодоксаль карашлы. *[Эйфель башнясын] вакытында, үз телләре белән әйткәндә, „ортодокс художниклар" яратмаганнар.* Г. Гали.

ОРТОДОКСАЛЬ *с. кит.* Тайпылышсыз нинди дә булса бер юнәлеш, тәгълимат принципларын яклаучы. || Эзлекле революцион (марксизм тарафдарлары һәм идеяләре турында). *Ортодоксаль марксист.*

ОРТОДОКСАЛЬЛЕК *и. кит.* Ортодоксаль булу сыйфаты. *Карашларның ортодоксальлеге.*

ОРТОДО'КСЛАНУ *ф. кит.* Ортодоксаль карашлы булып китү. *Казанда, Халиковның аңлатмаларына ышанып, бу ифрат яшь этәч булып кыйлана, артык ортодокслана дип карадылар.* А. Расих.

ОРТОПЕД *и.* Ортопедия белгече — врач.

ОРТОПЕ'ДИК *с.* Гәүдә һәм кул-аякларның кәкрәюен дәвалау өчен билгеләнгән. *Ортопедик гимнастика. Ортопедик аяк киеме.*

ОРТОПЕ'ДИЯ *и.* Медицинаның гәүдә һәм кул-аякларның кәкрәюен өйрәнә, дәвалый һәм кисәтә торган бүлеге.

ОРТЫН *рәв. сөйл. к.* орынтын. *Кайда тагын карт убырлар күз сала ортын гына.* Н. Исәнбәт. *Кайттым илләремә ортын гына, Кайттым яшерен генә, тын гына.* Ф. Бурнаш.

ОРУ *ф.* 1. Кемгә яки нәрсәгә бәрү, сугу. *Баш очына күтәргән авыр камчысын Миңнуллага орып өлгергәнче, кемдер, каты кизәнеп, сакчының башына*

таяк белән сукты. И. Гази. || Бер-берсенә каты итеп тидерү, терәү; бәрелдерү. *Айныгач та диңгез тыныч тормый: һаман дулкынлана, кузгала; Тик ташларны гына ташка ормый — Җир чигенә һаман кул сала.* Х. Кәрим. *Штаб башлыгы тагын бер тапкыр аягын аякка орып куйды.* Г. Бәширов. || Сугу, кыйнау. — [*Хатыныңны*] *яратмыйсың икән, орма, сукма, аер да җибәр.* Г. Камал.

2. Берәр нәрсәне читкә яки кем-нәрсә өстенә ташлау, ату. *Ашны кире кагуга караганда, таш белән ору артыграк.* Әйтем. *Гитлерны әйтәм, туң башны, Безнең совет туфрагына Йөз тоңналык фугасны Китереп-тереп ормасынмы!* Н. Исәнбәт. || *диал.* Ат башына йөгән кидерү турында. [*Мин Самат абыйдан*] *җир сөргә рөхсәт итүен үтендем.— Ниятең әйбәт, энем, — диде ул, — тик атка йөгән ора алырсың микән соң?* В. Нуруллин.

3. *күч.* һөҗүм итү, ташлану (дошманга). *Киңәш корды төнен кызыллар Соңгы көчне җыеп орырга.* Х. Туфан.

4. *күч.* һәлак итү, бәреп үтерү, юкка чыгару. *Кил, тотын кулга кул, ор залимны!* Н. Исәнбәт.

5. *рәв. мәгъ. күч. сөйл.* **орып.** Бик каты, көчле (яңгыр турында). *Орып-орып яңгыр яуган бер төннe, әти, мылтыгын брезентка төреп, өйдән чыгып китте.* Г. Ахунов.

◇ **Орып салу** — җиңү, кемнән яки нәрсәдән бик нык өстен булу. *Сүзгә-хәйләгә дисәң, Ясәви ике Сәет Батталыңны берьюлы орып салырлык.* Ф. Хөсни.

ОРУ'ДИЕ *и.* Артиллерия коралларының гомуми атамасы. *Кинәт, һаваны ярып, көчле орудиелəр залпы җыгырады.* Каз. утл. *Өченче залптан соң юнкерларның орудиеләре дə, пулеметлары да шып туктадылар.* К. Нәҗми.

ОРФОГРА'ФИК *с.* Орфографиягə караган. *Орфографик сүзлек. Орфографик хаталар.*

ОРФОГРА'ФИЯ *и.* Билгеле бер телдə сүзлəрне дөрес язуның гомуми кабул ителгəн кагыйдəлəр системасы. *Орфографияне ныклы үзләштерү.* □ *Татар әдәби теле орфографиясендәге соңгы үзгәрешләр язылыш белән әйтелеш арасындагы каршылыкны мөмкин кадәр бетерүне күздә тота.* Х. Курбатов. || *с. мәгъ. к.* орфографик. *Орфография күнекмәләре.* □ *Кыска гына җөмләдə дə орфография кагыйдəлəрен булдыра алган кадəр бозганнар.* А. Шамов.

ОРФО'ЭПИК *с.* Орфоэпиягə караган. *Татар теленең орфоэпик нигезләре.*

ОРФО'ЭПИЯ *и.* Әдəби дөрес әйтелешне билгели торган кагыйдəлəр системасы. *Орфоэпия буенча күнекмəлəр үткəрү.* □ *Хəзерге татар орфографиясендə законлаштырылган фонетик принципны без, төбендə, - - - орфоэпиянең орфографиягə йогынты нəтиҗəсе дип карарга тиешбез.* Л. Җəлəй. || Дөрес əйтелешне саклау. *Рус теле дəресләрендə укучыларның орфоэпиясен күзəтү.*

ОРХИДЕ'Я *и.* Чəчəкләре күпчелек очракта хуш исле һəм хикмəтле формалы төрле ачык төсләрдə булган күпьеллык үлəн үсемлек (эссе һəм урта пояслarда үсə). *Тропик урманнарда орхидея агач кабыкларында үсə, аның тамырлары һавада асылынып тора.* Робинзон эзл. || Шул үсемлекнең чəчəге.

ОРЧЫК *и.* **1.** Кул белəн җеп эрләү өчен бер башы тупыйк, икенче башы нечкə очлы, ə уртасы юантыграк итеп эшлəнгəн агач таякчыктан гыйбарəт корал. *Карт бар өйдə кот бар, Карчык бар өйдə орчык бар.* Мəкалъ. *Ал кабаны, эрлə җепне, Орчыгыңны ныкбөтер.* З. Байчурина.

2. Төрле механизмнарда, җайланмаларда əйлəнү күчəре хезмəтен үти торган кендек. *Капканың орчыгы тупсасыннан чыгу.*

Орчык сөяк — кешедə: белəк сөякләренең берсе; кошларда: балтыр белəн бармаклар арасындагы сөякләрнең берсе.

◇ **Орчык борын** — 1) кечкенə, очлы борын турында; 2) шундый борынлы кеше. **Орчык буе** — бик кечкенə. *Бу кадəр кеше арасында орчык буе малайны табып буламы соң?* Л. Исханова. **Орчык кебек (хəтле) генə** — 1) *к.* орчык буе. *Сабый имəн . . . орчык кебек кенə, Тик анда да нинди куəт бар.* Ш. Мөдəррис; 2) кечкенə гəүдəле, җитез, елдам (кеше турында). *Миңсылуның хəтта „бу сабый чырайлы, орчык хəтле генə хатын каян шулкадəр күп белə икəн?“ дип чыннан гажəпләнеп сөйләнгəн чаклары да булгалады.* Ə. Еники. **Орчык шикелле (сыман) бөтерелү** — 1) бик җитез хəрəкəтлəр ясап əйлəнə-əйлəнə бию турында. *Бераздан соң инде Захаров биергə, орчык шикелле бөтерелергə тотына.* А. Шамов; 2) берəр кеше тирəсендə, күңелен күрергə, ярарга, ярдəм итəргə тырышып, йөгереп йөрү. *Кунаклар тирəсендə орчык шикелле бөтерелеп йөрү.*

ОРЧЫКБАШ *и.* **1.** Орчык башына салмаклык өчен киертелə торган божра (җеп чорналып, орчык авырая башлагач, аны алып куялар). *Дни ачу белəн хатынның орчыкбашын тəгəрəтеп җибəргəн.* Əкият.

2. Шуңа охшашлы, шуны хəтерлəткəн нəрсə. *Эче куыш, тышы таш, Түбəтəе орчыкбаш.* Табышмак.

ОРЧЫКЛЫ *с.* Орчыкка (1 мəгъ.) бəйлəнешле, орчык белəн кулдан эрлəнгəн. [*Болгарга*] *мəрҗəн һəм орчыклы җеп, савыт-саба Русь иленнəн килгəн.* Г. Ахунов.

ОРЧЫКЧА *и. зоол.* Бакыр яки көрəн төсле, еланга охшашлы аяксыз кəлтəнең бер төре; бакыр кəлтə.

ОРШЫНУ *ф. диал.* Үз алдына тиргəшү, сукрану. *Мөфлиха абыстайның оршынуы артып, үч алу ниятe белəн, идəнгə тибеп куй* [*ды*]. Н. Думави. *Шаммас уйга чума, - - - үзенең тетмəсен тетеп оршына.* Б. Камалов.

ОРШЫШ *и. диал.* Ызгыш, талаш. *Ник лазем ялган сөйләү, Һəм ник кирəк оршыш кылу.* Н. Думави.

ОРШЫШУ *ф.* Əрлəшү, тиргəшү (кем белəн дə булса). *Минһаж, кара-каршы оршышкан ирлəр тавышы ишетеп, шул якка килə һəм салам түбə астыннан ятып карый.* С. Баттал. *Хафиз булган мəҗлес шау-шусыз үтми. Мəйданда Хафиз шаулый, мəҗлестə Хафиз оршыша.* И. Рəмиев. *Дни белəн хатын оршышканнар ахры.* Əкият.

ОРЫ *и.* **1.** Кеше яки хайван тəнендə зур булмаган каты үсенте, үлексез шеш; *русчасы:* желвак, шишка. *Ора белмəгəннең орысы чыгар.* Мəкаль.

2. Кайбер хайваннарның башында, борын, күз тирəсендə тумыштан кабарып торган кечкенə үсенте; *русчасы:* нарост. *Борын өстe орылы голански ата казлар буламы? Була.* Каз. утл.

3. Агач кəүсəсендə, ботакларында яки тамырында бүлтəеп торган авыру үсенте (агач кəүсəсендəгесе төрле эшлəнмəлəр өчен файдаланыла); *русчасы:* кап. *Бу тирəк искиткеч ямьсез тирəк иде, - - - бик күп урыннары зур-зур орылар белəн капланган.* М. Əмир.

ОРЫЛЫ *с.* Орысы булган. *Орылы борын. Орылы тамыр.*

ОРЫЛЫП-БƏРЕЛЕП, ОРЫЛЫП-СУГЫЛЫП *рəв.* Кем яки нəрсəлəргə орынып, бəрелеп, кагылып. *Мəбрүрə, баскычтан очкан кебек төшеп, орыла-бəрелə кача.* М. Фəйзи. *Вагон халык белəн шыгрым тулы иде: утырыр урын таба алмыйча, шактый озак орылып-сугылып йөрергə туры килде.* Г. Сабитов.

ОРЫН *рəв. диал. к.* орынтын. *Орын эшлəү.* | *с. мәгъ.* [*Бикташ*] *орын ишектəн чыгып китə.* Т. Гыйззəт.

ОРЫНДЫРУ *ф.* Нәрсәгә дә булса бәрдерү, әләктерү. *Капка баганасына орындырып, чана мөгезен сындырганбыз.* Х. Кәрим.

ОРЫНМА *и. мат.* Әйләнә белән бер генә уртак ноктасы булган туры. *Әйләнәгә орынма үткәрү. Әйләнәнең орынмасы турындагы теоремалар.* || *с. мәгъ. физ., мат.* Нәрсәгә дә булса орынып торган. *Орынма юнәлеш. Орынма магнит угы. Орынма сызык. Орынма яссылык. Орынма юнәлеш.*

ОРЫНТЫН *рәв. сөйл.* Астыртын; яшерен (рәвештә). *Орынтын эшләү.* | *с. мәгъ.* — *Нишләргә?.. Әйе, әйе, китәргә. Орынтын юллар белән анда барып хәбәр итәргә.* Т. Гыйззәт.

ОРЫНУ *ф.* Тию, кагылу; тиеп, кагылып китү. *Ялгыш орынып киткән саен, агачлардан шабырдап су коела; аяк асты пычрак, тайгак.* И. Гази. — *Я, Нәҗия, ник дәшмисең?* — *диде ул, кызның тезләренә йомшак кына орынып.* Ә. Еники. || Каты һәм кинәт бәрелү. *Хәлим килеп орынуга, егет сөртенеп китте.* Г. Гобәй. *Пароход пристаньга килеп орынды.* Г. Минский. || *рәв. мәгъ.* **орынып**. Бик якын, янәшә. *Бакча елгага орынып тору.* □ *Ул безнең орынып кына торган күрше малае.* Ш. Маннур.

2. Нәрсәгә дә булса рөхсәтсез тотыну, кагылу, тию. *Элек чыбык-чабыкка орынырга котлары алынып торган кешеләр хәзер алпавыт урманына үз бакчаларына кергән кебек кыю керәләр.* И. Гази. || *күч.* Кемнең дә булса иминлеген, тынычлыгын бозу; һөҗүм итү. [*Митрофанов белән Садрый байларга*] *орынган кеше төрле нужага тартылды.* Г. Толымбай. [*Бәеттә*] *ватан иминлегенә орынган теләсә генә нинди дошманны да җимерәчәгенә* [*лирик геройның*] *тирән ышанычы, сүрелмәс оптимизмы аңкып тора.* Х. Госман.

3. *күч.* Тәэсир итү, тәэсирен сиздерү. *Көз сулышы бөдрә каеннарга да орынды.* Г. Әпсәләмов. *Гасырларча азгын, коры җилләр Искән һаман җиргә орынып.* Ш. Мөдәррис.

Орыну ноктасы *мат.* — орынма туры һәм кәкре сызыклар өчен уртак булган нокта.

◇ **Орынып тору** — 1) бик якын, янәшәдә генә булу. *Өйдәгеләр, диссертациясен язып бетергәч, Тимерханның вакыты иркенәер, орынып ук торган Кама буена чыгарбыз... диеп өметләнгәннәр иде.* Каз. утл.; 2) күршедәш, чиктәш булу. *Көнчыгыш Европа халыклары белән орынып торган Болгар иленә Көнчыгыш, бигрәк тә Урта Азия дәүләтләре кызыксынып карыйлар.* Каз. утл.

ОРЫНУЧЫ: орынучы әйләнәләр *геом.* — бер уртак нокта белән бер-берсенә орынып торган әйләнәләр.

ОРЫНЧАК *с.* Нәрсәгә дә булса җиңелчә бәрелеп, гел ышкынып йөри торган. *Орынчак атта ял юк.* Мәкаль.

ОРЫП-БӘРЕП *рәв.* **1.** Бик каты, чиләктән койган кебек (яңгыр турында). *Урман эчләрен айкап, аллы-артлы яшен яшьнәде, ул да түгел, орып-бәреп яңгыр яварга тотынды.* Г. Ахунов.

2. *сөйл. к.* орды-бәрде 1. *Орып-бәреп кенә эшләү.*

3. *сөйл.* Эткәләп, төрткәләп. *Халык арасыннан орып-бәреп үтеп китү.*

ОРЫП-ЕРЫП, ОРА-ЕРА *рәв.* Кискен хәрәкәтләр белән аралап, ике якка эткәләп. *Менә ул, чуалган сафларны ора-ера алга атылып, Мохтар агайны куып җитәргә --- ашыкты.* Г. Минский.

ОРЫП-СУГЫП *рәв.* Кыйнап, җәберләп. — *Мин, башка аталар кебек,* [*кызымны*] *орып-сугып, мин әйткәнгә бар дип, көчләмим.* М. Фәйзи. *Әсирләрне бу дәрәҗәдә җәбер кылып, орып-сугып ачлы-туклы хезмәт иттерү — һич* [*инсаниятлек түгелдер.* Ш. Мөхәммәдев.

ОРЫШ *и.* **1.** Тиргәү, битәрләү сүзләре. *Көне буе югалып йөргән өчен әти дә, әни дә орыша торган булсалар да, аларның бу орышлары зәһәрле, йөрәк әрнет*[*кеч*] *--- тәэсир калдырмый иде.* М. Гафури. [*Асрау кыз:*] *Көне-төне эшлисең дә эшлисең, аның өстенә һәр көн орыш та талаш.* Г. Камал. || Ызгыш, талаш. *Яхшы хатын — ырыс, Яман хатын — орыш.* Мәкаль. *Орыш вакытында* [*Рәгыя*], *үзен-үзе белмичә җенләнә башлап, кисәү агачы белән бәреп, бер хатынның күзен чыгара.* Г. Ибраһимов.

2. *иск., диал.* Сугыш, бәрелеш. *Байтирәк урманы буенда патша армиясе белән бик каты орышлар булган.* Г. Бәширов. *Идел йортка көнчыгыштан зур яу килгән. --- Иртә таңнан кара төнгәчә орыш барган.* А. Гыйләҗев.

ОРЫШ-КЫРЫЛЫШ *җыйм.* **1.** Бик каты талаш, дау.

2. Каты, кан койгыч сугыш.

ОРЫШ-ТАЛАШ *җыйм.* Ызгыш, кычкырыш, бик каты тиргәшү. *Өйгә кайтсам, орыш-талаш китә.* Ш. Маннур.

ОРЫШУ *ф.* **1.** Тиргәү, битәрләү, бик нык ачуланып. *Су анасыннан котылгачтын, тыныч лангач, әни И орышты, и орышты, и орышты соң мине.* Г. Тукай. — *Д сез беләсез, дуслар, үзеңне үзең орышудан да каты орышу юк дөньяда.* А. Шамов.

2. *иск.* Сугышу, һөҗүм итү. *Бу Курган калган икән борын ханнан, Ул хан үзе булган мөселманнан. Тарих мең дә биш йөз утыз елда Орышып урыс патша алган аннан.* Каз. утл.

ОСЕТИН *и.* Төньяк Осетия АССР һәм Көньяк Осетия автономияле өлкәсендә яшәүче төп халыкның атамасы, шул халыкның бер кешесе. *Минем хыялым — язучы булу. Мин --- осетин врачы Саслан Даутович кебек чын кешеләр турында язачакмын.* М. Хөсәен.

ОСЕТИ'НЧА *рәв.* Осетин телендә.

ОСЁТР *и.* Кыйммәтле ите һәм уылдыгы белән дан тоткан эре балык; мәрсин балыгы. *Тезгештә сазаннар һәм ике зур осётр бар иде.* Г. Минский.

ОСЁТРЧАЛАР *и. күпл. зоол.* Осетр, кырпы, чөгә, укбаш балыклары керә торган семьялыкның атамасы. *Кеше өчен бик кыйммәтле --- һәм бөтенләй кырылып бетүдән саклауга мохтаж булган күп кенә хайваннарны күрсәтергә мөмкин. Балыклардан боларга иң беренче чиратта лососьлар, осётрчалар керә.* Биология.

ОСКЫТУ *ф. диал.* Котырту. *Аңа каршы сүз әйтеп, аны кирәкмәскә оскытуның ни мәгънәсе бар?* Ф. Хөсни.

ОСТА *и.* **1.** Нинди дә булса һөнәр белән шөгыльләнүче квалификацияле эшче, һөнәрче. *Сәгать остасы. Балта остасы.* □ *Һәр эшнең үз остасы бар.* Мәкаль. *Килделәр осталар балтасыз, Салдылар йорт тактасыз.* Табышмак. *Аягында фетр итек, Кем эшләгән ак итеп? — Эшләнә ул Казанда, Үзем остә мин анда!* Ш. Маннур.

2. Үз эшенең зур белгече, үзенең эшен бик яхшы башкара алуга ирешкән кеше. *Музыка остасы. Нәфис сүз остасы. Югары уңыш осталары.* □ *Бию көе бию остасында ничек дәрт кузгатса, аучы карт өчен дә мылтык тавышы шундый булды.* Г. Минский. *Бакулардан монда кайтты, Үз илендә ирек тапты; Соң бит үзебездә нефте, Ул бит шуның остасы.* Н. Исәнбәт. || Нинди дә булса эшкә осталык, маһирлык күрсәтүче кеше. *Шәпеш хәлфә шәкертне кыйнаудан битәр, кыйнамый гына үзәгенә үтә белә, һәм ул моның тиңе юк остасы иде.* Ә. Фәйзи.

3. *к.* мастер 2. *Башлыгыбыз, юл остасы, начар кеше түгел иде.* Ш. Камал.

4. *с. мәгъ.* Нәрсәгә дә булса осталыгы, тиешле күнекмәсе, тәҗрибәсе булган. *Оста итекче бер пар итекне ике көн эчендә тегеп бетерәдер.* Г. Тукай. *Оста ялганчы дөрес сүз эченә генә ялган кушар.* Мәкаль. || Нәрсәгә дә булса осталыгы, күнекмәләре булу күренеп торган. *Оста кулда һөнәр бар.* Мәкаль.

5. *рәв. мәгъ.* Яхшы белеп, яхшы сыйфатлы итеп, матур итеп, җиренә җиткереп. *Оста җырлау. Оста сөйләү. Оста бию.* □ *Бергә чабаталар үреп йөргән чакта, Син остарак миннән үрә идең.* Һ. Такташ. — *Җиңгәгез тары коймагын оста пешерә, --- әйдә, рәхим итегез.* М. Әмир. | *хәб. функ. Эшкә оста, сүзгә кыска — һәркем аны ярата.* Ә. Исхак.

Оста куллар түгәрәге — укучыларны төрле кул һөнәрләренә өйрәтә торган түгәрәк.

◇ **Оста телле** — матур, шома һәм кызыклы итеп сөйләүче.

ОСТАБИКӘ *и.* 1. Мулла хатыны. *Яшел чапан кияр бу, Ап-ак чалма чорнар бу; Остабикә кирәк дип, Бер бай кызын сорар бу.* Г. Тукай. *Мулланың остабикәсе чи надан булганлыктан, сабак укырга килгән кызларга --- теше үтеп бетми иде.* Ф. Хөсни.

2. *иск.* Мөгаллимә. *Авылның олылары да: — Зөһрә ул акыллы да, матур да, укымышлы да, остабикә булырлык кыз, — дип сокланып сөйлиләр.* Х. Мөҗәй. — *Хатын, укуың җиткән икән, остабикә буласың гына калган хәзер, — дип, [Ярхәм] хатынының аркасыннан кага.* М. Гали.

ОСТАЗ *и. кит.* 1. Укытучы; фән белән таныштыручы, берәр яхшы һөнәргә өйрәтүче кеше. *Һәр эшнең остасы бар, һәр останың остазы бар.* Мәкаль. *Оста барда кулың тый, остаз барда телең тый.* Мәкаль. *Тәһир белән Зөһрә остазлардан Сабак ала диеп сөйлиләр.* Ф. Бурнаш. || Берәр төрле эшкә, һөнәргә юл күрсәтүче, юнәлеш бирүче, үрнәк күрсәтүче. *Мәктәбислектә Жуковский — зур остазым минем.* Г. Тукай. *Ямангa өйрәткән остазың Менгерде башыңны казыкка.* Н. Исәнбәт.

2. Мәсләгенә бик күпләрне өйрәткән өлкән, җитәкче кеше. *Безнең остазларыбыз, коммунизмга иске җәмгыятьнең пычрагын сөйрәп бармаска, кешене аннан арындырырга кирәк, дип өйрәтәләр.* Г. Бәширов.

ОСТАЗБИКӘ *и. иск. к.* остабикә 1. *Мулла белән остазбикә бер-берсенә карашып алдылар, кашларын җыердылар.* А. Шамов.

ОСТАЗЛА'РЧА *рәв.* Остазлар кебек. *Ильяс --- бөтенләй җитди, бөтенләй остазларча җай гына сөйләп китә.* Р. Төхфәтуллин.

ОСТАЗЛЫК *и.* Остаз булу хәле. *Муллалар үзләренең тарих белән килгән остазлык [хокукларына] таяналар.* Г. Ибраһимов.

ОСТАЛА'РЧА *рәв.* Һөнәр осталарына хас булганча; осталар кебек. *Октябрьның ун еллыгын без яңа татар әдәбиятының осталарча язылган әсәрләре --- белән каршы алабыз.* К. Нәҗми.

ОСТАЛЫ *с.* Осталарга бай, осталарга ия булган. *Осталы ил узар.* Мәкаль.

ОСТАЛЫК *и.* 1. Нәрсә дә булса эшләргә белем, тәҗрибә нигезендә туган сәләт. *Рәсем төшерүгә осталык. Эшкә осталык.* □ *Бүген бездә әдәби осталык мәсьәләләренә аеруча нык игътибар итәргә кирәк.* Р. Мостафин. *Менә хәзер ул район прокуратурасында тикшерүче. Елдан-ел Сәгъдиевнең тәҗрибәсе, осталыгы үсә бара.* Каз. утл. || Берәр өлкәдә зур һәвәслек, маһирлык; нинди дә булса эшне оста башкару сыйфаты. *Икенче бер егет, аңа каршы төшеп, үзенең биюгә осталыгын күрсәтергә кереште.* М. Гафури. *Бу урыннарда табигать төзү ягыннан төрлелек бирә алуда үзенең искиткеч осталыгын күрсәткән.* Ш. Камал.

2. Оста (3 мәгъ.) хезмәте, вазифасы. *Осталыкка ялланy.* □ [*Җиһанша хәзрәтнең*] *кәсеп турысында булган фикере --- һөнәрдә, осталыкта тимерче Якуп агайның һөнәреннән үтми иде.* З. Һади. || Оста вазифасын үтәүче. *Бу озын буйлы, калын гәүдәле, ярым русча киемле карт --- рус тегермәнендә осталык хезмәтендә торучы икән.* Г. Ибраһимов.

3. Нинди дә булса максатка ирешүдә тапкырлыкка яки хәйләкәрлеккә, елгырлыкка нигезләнеп эш итү ысулы. *Гомеремдә моның ише осталыкны, хәйләкәрлекне күргәнем дә, белгәнем дә юк иде.* Г. Минский. — *Әгәр дә әхмәтне бик осталык белән алдыйсыгыз килсә, бүген төнлә өенә барыгыз.* Д. Аппакова.

ОСТАРУ *ф.* Остага эйләнү, нинди дә булса эшне оста итеп эшләргә, башкарырга өйрәнү. *Без бик яшьли Корыч мушка аша Дошман күзәтергә остардык.* М. Җәлил. *Бара торгач, тоткыннар шул чаклы остаралар: икесе ике камерадан торып чиертешкәндә, гади сөйләшеп утырган кебек тиз аңлаша башлыйлар.* Г. Ибраһимов.

2. *ирон.* Белдеклеләнеп сөйләнү. *Директор да агрономның остаруын урынсыз тапты.* Ф. Сәйфи-Казанлы. — *Телеңне кисеп алырга иде синең, урынлы-урынсыз остарганың өчен.* Ф. Хөсни.

ОСТИТ *и. мед.* Сөякнең ялкынсынуы.

ОСЦИЛЛОГРА'ММА *и. махс.* Осциллограф белән язып алынган кәкре сызык. *Программистлар һәм аңлатучылар пультында осциллограмма төргәкләре озын рәтләргә тезелеп барды.* Соц. Тат.

ОСЦИЛЛО'ГРАФ *и. махс.* Техникада, медицинада һ. б. электрик процессларны күзәтү һәм язу өчен кулланыла торган прибор

ОСЦИЛЛОСКОП *и. физ.* Электрик процессларны гади күз белән күзәтү өчен махсус прибор.

ОТДЕЛЕ'НИЕ *и. хәрби.* Армия сафында иң кечкенә гаскәри берләшмә, взводның бер өлеше. *Отделение командиры.* □ *Укчы ротадан разведкага җибәрелгән Газинур отделениесенең бурычы һөҗүм алдыннан дошман оборонасының характерын ачыклау иде.* Г. Әпсәләмов.

ОТЕЛЬ *и.* к. гостиница. *Кич җитәр алдыннан, Майсур шәһәренең бер читендәге зур яңа отель янына барып җиттек.* М. Мәхмүтов.

ОТЗОВИЗМ *и.* РСДРПда 1905 елгы революциядән соң барлыкка килгән һәм Дәүләт думасыннан социал-демократик депутатларны чакыртып алуны, массачыл партия эшенең легаль формаларыннан баш тартуны таләп иткән оппортунистик агым. *Ликвидаторлыкның һәм отзовизмның килеп чыгуының сыйнфый тамырлары бар иде.* КПСС тарихы.

ОТЗОВИСТ *и.* Отзовизм тарафдары. *Отзовистлар партиянең яшәвенә астыртын рәвештә куркыныч китерделәр.* КПСС тарихы. *Ленин җитәкчелеге астындагы большевистик агым --- һәр ике якка — уңга — ликвидаторларга, „сулга“ — ультиматистларга-отзовистларга — каршы каты фронт белән сугыш алып бара.* Г. Ибраһимов.

ОТКЫР *с.* Үтә зиһенле, тиз отып алучы һәм яхшы хәтерле. *Гайнелгыйбад Хәсәновны — үзеннән-үзе укып, хезмәтчедән анатомия белгече булып әверелгән откыр кеше димичә, ни дисең?* И. Рәмиев.

ОТЛИ'ЧНИК *и.* 1. Барлык төп уку предметларыннан иң югары бәя алган укучы. *Уку отличнигы.* □ *Пионерга бер көнне кердек, ул отличник булса, мин дә отличник.* Г. Гобәй.

2. Үз эшен, үз өстенә төшкән бурычны югары сыйфатлы итеп үтәүче кеше. *Совет сәүдәсе отлич-*

никлары. □ — *Менә кара, бусы — узган ел ударниклар белән төшкән рәсем, --- бусы — отличниклар бригадасында.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ОТЛИ'ЧНО *рәв.* 1. Бик яхшы, бик әйбәт (эшкә иң югары бәя биргәндә әйтелә). [*Сәяхәтче*] *отлично укучылар гына баралар.* Д. Аппакова. | *с. мәгъ. Минем смена нормаңы йөз процентка үтәп килә. Отлично сыйфат белән.* Р. Ишморат.

2. *сөйл. модаль сүз функ.* Нәрсә белән дә булса тулысынча килешүне, шуны хуплауны белдерү өчен кулланыла. [*Гали:*] *Иртәгә миңа бар. Ничек-ничек бүлешеп тәрҗемә итәсең сөйләшербез.* [*Газиз:*] *Отлично.* Ф. Әмирхан.

3. *и. мәгъ.* Белемнәрне, тәртипне билгели торган иң югары бәя. *Сынауда студияне тәмам итүче җырчыларның егерме икесе „отлично", унысы „яхшы" билгеләре алды.* М. Җәлил.

ОТПОР: отпор бирү *сөйл.*— һөҗүмне кире кайтару; кискен каршылык күрсәтү. *Дзер тора отпор бирергә ул Кирәк чакта явыз дошманга!* З. Мансур.

О'ТПУСК *и. сөйл.* Ял итү, дәвалану өчен закон тәртибендә билгеле бер вакытка эштән, хезмәттән азат итү. *Санбат врачлары мине ял итү өчен 3 айга отпускка җибәрделәр.* Ә. Айдар. — *Менә озакламый отпуск алам, аннан икәүләп Кавказга ял итәргә китәрбез.* Т. Гыйззәт.

ОТРЯД *и.* 1. Махсус гаскәри группа. *Атлы отряд. Партизаннар отряды. Десантчылар отряды.* □ *Бишбалтада беренче Кызыл Гвардия отрядлары төзелә.* К. Нәҗми. *Күчәргә җыенып һөҗүмгә тагын да, Тупланды отрядлар шәһәрнең янында.* Ә. Исхак.

2. Бергә эш алып бару яки аерым йөкләмә үтәү өчен оештырылган кешеләр төркеме, коллектив. *Геологлар отряды.* □ *Бу ике отряд пионерлары бер ата балалары кебек дуслаштылар.* Г. Гобәй. *Соңгы елларда безнең театрларда күп кенә яңа әсәрләр куелды. --- Бу өлкәдә безнең зур гына драматурглар отряды эшләп килә.* Б. Гыйззәт.

3. *зоол.* Хайваннар дөньясы классификациясендә: зур төркем. *Кимерүчеләр отряды. Ерткычлар отряды.*

ОТСТА'ВКА *и.* Хәрби хәзмәттән бөтенләйгә азат ителү, китү; шулай ук (революциягә кадәр) дәүләт учреждениесендәге хезмәттән бөтенләйгә китү. *Отставкадагы генерал.*

Отставкага чыгу (китү) — 1) *к.* отставка. *Аның --- подполковник дәрәҗәсендә отставкага чыккан-лыгын Заһид ишетеп белә иде.* А. Расих; 2) парламентның ышанычсызлык вотумы яки дәүләт башлыгы алмашыну уңае белән властьтан китү (хөкүмәт яки кабинет турында); 3) *күч.* картаю, эшкә яраксыз хәлгә килү.

О'ТТИСК *и. махс.* 1. Текстның, рәсемнең һ. б. ш. полиграфик ысул белән алынган күчермәсе. *Оттисклары, корректор карап чыккач, редакторга җибәрделәр.* Г. Минский.

2. Журналда яки җыентыкта басылган мәкаләнең аерым брошюра формасындагы төпләмәсе. *1830—1850 елларда, безнең исәбебезчә, университет типографиясендә 536 китап, журнал һәм оттисклар басылган.* Каз. утл.

ОТТОМА'НКА *и.* Арка сөягече алынмалы махсус мендәрләрдән торган киң диван.

ОТТЫРУ *ф.* 1. Нәрсәдән дә булса (акчадан, әйбердән) мәхрүм булу; югалту, зарар күрү (карта, биллиард һ. б. төрле комарлы уеннарда). [*Полковниктан*], *карта уйнап, ике йортны оттыруы турында хәбәр килә.* К. Нәҗми. *Яше унҗидегә җиткәч, биллиард уйный башлыйдыр, Бер-ике йөз сум оттыргач, җилкәсене кашыйдыр.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Уңмау, уңышсызлыкка дучар булу. *Бу өйләнүендә ул шактый оттырды.* Ә. Фәйзи. [*Аның*] *алтын киңәшен вакытында колакка алмый оттырдым.* М. Әмир.

3. Җиңелү (уенда, ярышта, көрәштә, бәхәстә һ. б.). *Футбол уенында зур исәп белән оттыру.* □ *Һөҗүм башлауны һич кичектерергә ярамый. Дошманга яңа көч тупларга вакыт бирсәк, үзебезнең оттыруыбыз бар.* Ф. Кәрим. — *Синең отылуың, Хазбулат, минем өчен дә авыр. Мәйданда бер оттырдың инде, әгәр тагын оттырсаң...* Р. Ильяс.

ОТТЫРЫШ *и.* 1. Оттырылган нәрсә, сумма (карта, лото һ. б. комарлы уеннарда). *Оттырышны кире кайтарырга тырышу.*

2. Җиңелү, уңышсызлык (уенда, ярышта, бәхәстә, сугышта һ. б.). [*Фашистлар*] *хәтта сугыштагы оттырыш өчен коралсыз әсирләрне дә җәзалап үтерүдән кул тартмаслар.* Н. Дәүли.

3. Зарар, югалту.

ОТТЫРЫШЛЫ *с.* Оттыра торган (комарлы уеннарда); *киресе:* отышлы. — *Безнең якта оттырышлы уеннар уйнамыйлар шул.* Ю. Әминов.

ОТУ *ф.* 1. Отышлы уенда җиңеп, салынган акчаны, кассаны алу. *Кичә бу --- малайны кызык иттем. Карта уйнадык, 42 сум акчасын оттым.* Ф. Әмирхан. || Акчалы яки әйберле отыш чыгу, отыш алу (заем, лотерея, спортлото тиражлары уйнаганда). *Лотереяга машина оту.*

2. Нәрсәне дә булса үз файдаңа хәл итү, җиңеп чыгу (уенда, ярышта, бәхәстә, сугышта һ. б.). *Таң алдыннан алар, елга аша Хәйлә өчен көчле басым ясап, Каршы якны утка тоттылар һәм сугышны бик тиз оттылар.* Ә. Исхак. *Кара мыеклы бер агай Шахмат уйнап дустын откан.* Г. Латыйп. *Отыйм дигәндә тотылдым, Соңыннан көчкә котылдым.* Г. Кандалый.

3. Нинди дә булса файда, өстенлек алу. — *Акыллырак кешеләр әйтә: патша гаскәренең җиңелүеннән патша гына оттыра, ә халык ота, ди.* Ә. Фәйзи. *Әсма, Патый әгәр шундый хатынның кодагые була калса, ниләр отачагын барысын да санап чыкты.* М. Галәү.

4. Бик тиз өйрәнү, ятлау, хәтердә калдыру (күргәннe, ишеткәнне, өйрәткәнне һ. б.). *Яңа көй оту.* □ *Яңа аңа — ул чын хәким кеше, От мәгънәсен һәрбер сүзенең.* Н. Арсланов. *Кичә бер җыр откан идем, Ул да бүген онытылган.* М. Фәйзи. || *күч.* Үрнәк итеп алу, файдалану. *Ике колхоз, елдан-ел дуслаша барып, берсен-берсе алга әйдиләр, берсендәге яңалыкны икенчесе отып, көнләшә-көнләшә эшлиләр, кыз бирешәләр.* Г. Бәширов.

Отып алу — 1) *к.* оту 1; 2) өйрәнү, ятлау. *Ерак йөргән чакта чүл буйлап, Шушы җырны отып алдым мин.* Ә. Ерикәй.

ОТЫЛУ *ф.* Оттырышка, уңышсызлыкка дучар булу; оттыру. *Карта уенында отылу.* □ *Икеләнүләр аркасында мин еш кына отылам.* Г. Галиев. — *Миңа, Исмәгыйль отылды, дигән сүзне ишетмәү кыйбат.* М. Фәйзи.

ОТЫРЫ *рәв. сөйл.* Аның саен, торган саен, һаман. *Котыра чал давыл, Отыры каныга, Куалый көймәне Ят илләр ягына.* Х. Туфан. [*Дбинең*] *хәле --- отыры да начарлана барды.* Ә. Еники.

ОТЫРЫДАН-ОТЫРЫ *рәв. диал.* Торган саен, тагын да көчлерәк. *Мин, һаман яр кырыена баскан килеш, аның отырыдан-отыры ераклашканын карап тордым.* Г. Рәхим.

ОТЫШ *и.* 1. Комарлы уенда (картада, лотода һ. б.) отып алынган нәрсә, сумма. *Балыкчы* [*домино сугуда*]

уенны зур отыш белән түгәрәкләде. Г. Минский. || Заем, лотерея уйналганда отып алынган нәрсә. *Зур суммалы отыш. Заемның отыш номерлары басылу.* □ *Осоавиахим лотерея билетларының һәр тиражы уйналган саен, - - - Гәрәйгә дөньяны очып әйләнү отышы чыгар төсле тоела.* А. Алиш.

2. Җиңү, нәрсәдә дә булса ирешелгән уңыш.

3. Файда, өстенлек. — *Бер ел әллә ни зур югалту түгел. Әмма шул югалту бәрабәренә син нинди дә булса отыш алырга тиеш идең ләбаса.* Х. Вахит. — *Алай-болай булганда, ул яктан да [Фәхриягә ия булу ягыннан да] синең отыш булу ихтимал икән.* Ш. Камал.

ОТЫШЛЫ *с.* **1.** Отышка (1 мәгъ.) хокук бирә торган. *Отышлы уен. Отышлы заем.*

2. Файдалы, максатка туры килә торган, уңышка китерә торган. *Бу гөрелтедә Суганов, менә хәзер төркем тынып эшткәч, сүзне ничек отышлырак башлап китү турында уйлады.* Г. Минский. *Совхоз белән багланышның безнең өчен отышлы минуты алда иде әле.* М. Әмир. || Уңышлы, яхшы эшләнгән (әдәби образлар турында). *Г. Камалның тагын бер отышлы типларыннан асрау типлары хисапланалар.* М. Гали. | *хәб. функ.* [*Бу*] *әсәрләр материалны тормышның иң кискен бәрелешләреннән, иң текә борылышларыннан алып язылулары белән отышлы.* Л. Ихсанова.

ОТЫШХАНӘ *и. иск.* Комарлы уеннар өчен махсус йорт, бина. *Отыш уенчылар бу мәмләкәткә [Монакога] киләләр, оталар, оттыралар; отышханә иясенә вә падишаһчыкка һаман табыш.* Г. Тукай.

ОФИЦЕР *и.* Армиядә һәм флотта командирлар составындагы кеше. *Совет армиясе офицерлары.* □ *Өйдә бишләп офицер, Бәли бай, староста чәйләп утыралар иде.* Һ. Такташ. || *с. мәгъ.* Офицерларга бәйләнешле. *Офицерлар составы. Офицерлар кадры.* □ [*Күлдән*] *утыз-утыз биш метрлар чамасы эчтәрәк офицерлар блиндажы.* Ф. Кәрим.

ОФИЦЕРЛЫК *и.* Офицер дәрәҗәсе, чины. *Офицерлыкка күтәрү.* || *с. мәгъ.* Офицер дәрәҗәсенә хас; офицер хезмәтенә бәйләнешле. — *Юк, ул минем куркаклыгым түгел. Ул — офицерлык намусымны тиешле дәрәҗәдә тоту гына.* А. Шамов.

ОФИЦЕРЛА'РЧА *рәв.* Офицерларга хас булганча. — *Мин сезгә офицерларча сүз бирәм: сезне үтермәячәкләр.* Г. Әпсәләмов. — *Бай кызларының офицерларча киенгәнне яратканын Мәнди анасы да белә бит!* Ф. Әмирхан.

ОФИЦИАНТ *и.* Ашханәдә, ресторанда өстәлгә ашамлык-эчемлек китереп бирүче хезмәткәр. *Ул арада официант тирән тәлинкәләр белән куе кайнар токмач китереп өстәл өстенә куйды.* Г. Гобәй.

ОФИЦИА'НТКА *и.* Хатын-кыз официант. *Официантка белән исәп-хисапны өзеп, торып чыгып киттем.* Ф. Хөсни.

ОФСЕТ *и. махс.* Китап басуның бер ысулы: буяу басма формадан резина өлеккә, аннан кәгазьгә күчерелә. || *с. мәгъ.* Шуңа бәйләнешле. *Офсет басма.* □ *Менә дигән офсет кәгазенә басылган, һәр сызыгы, һәр ноктасы нечкә төгәллек белән башкарылган бу альбом бик кадерле истәлек иде.* А. Гыйләҗев.

ОФТАНУ *ф. к.* уфтану. *Шәмси, як-ягына каранган, офтанып куйды.* Г. Бәширов. *„Безнең тирәдә дә шундый яңгырлар булса икән!" — дип офтанып куйдым.* Ш. Камал.

ОФТАНУЛЫ *с.* Офтану хисе белән сугарылган. [*Мәликә*] *ярым офтанулы, ярым сагынулы - - - тавыш белән: — Мәгәр мин фермага йөрүдән туктый алмамдыр, — диде.* Г. Галиев.

ОФЫК *и.* **1.** Күкнең җир яки су өсте яссылыгы белән тоташкан сыман булып күренгән сызыгы; горизонт. *Ераста, офык буенда, Бер йолдыз яна.* Ф. Кәрим. *Офыкка сылап куелган күгелҗәм кара урман әкрен генә бер якка авыша бирә.* И. Гази. || Күкнең шул уйланма сызык өстендәге өлеше. *Ерактан ал таң сызыла, Офыкка сибеп нурын.* Ә. Исхак. *Давыл килә бугай чүл ягыннан, Өермәләр калка офыкта.* Х. Туфан. || Күз күреме иңли алырлык зур мәйдан, ераклык. *Офыктан офыкка кадәр җәелеп, арыш кырлары чайкалып ята.* М. Хәсәнов.

2. *күч.* Эш-хәрәкәт, мөмкинлекләр даирәсе. *Халидәне чолгап алган офык та башка, шулай ук ул хәрәкәт итә торган мәйдан да чагыштырмаслык киң.* Ф. Хөсни. *Әдәбиятыбызның офыклары киңәя бара.* З. Мәҗитов.

ОХ *ы. к.* ой **2.** — *Ох, кара син аны — безнең Нияз Салиховичны — ул нинди олы җанлы изге бәндә икән.* Х. Вахит.

О'ХРА *и.* Сары яки кызыл төстәге табигый минераль буяу.

О'ХРАЛАУ *ф.* Охра белән буяу.

ОХРА'НКА *и. сөйл.* Революциягә кадәрге Россиядә полициянең яшерен күзәтү оешмасы. *Охранка агенты.* □ *Хәбиб Мансуровны мылтыклы, кылычлы ике каравыл астында охранкага алып киттеләр.* Г. Ибраһимов. || Шул оешма урнашкан бина. *Шәһәрнең охранкасын яндырган чакта, кулга төшкән кәгазьләр арасында партиянең бик күп эшлеклеләрен тоттырган провокатор Осиповның да рәсеме чыкты.* Ш. Усманов.

ОХШАТУ *ф.* **1.** Кем яки нәрсә белән чагыштырып, ике арада охшашлык, уртак билгеләр, сыйфатлар табу, билгеләү. *Газизәне ул нәкъ шушы Хәлимәгә охшата.* Ш. Камал. *Өелешеп-өелешеп торган бу йолдызларны нинди шагыйрь иләккә охшаткандыр — хәзер берәү дә белми.* Г. Әпсәләмов. || Кем яки нәрсәгә охшаш дип санау. *Ул кайсы романны укыса, шуның кыз каһарманын үзенә охшата.* Г. Ибраһимов.

2. Кем яки нәрсәгә охшаш итү, охшаш итеп күрсәтү. *Җилнең эче поша. Кырларны дыңгезгә охшатырга тырыша, дулкыннар ясый.* Һ. Такташ. *Байтирәк малайлары хәтта кием-салымнарын да укытучы абыйлары киеменә охшатырга тырыша башладылар.* Г. Бәширов.

3. *и. мәгъ. әд. к.* чагыштыру **3.** *Бу шигырьдә бик ятышсыз, аңлаешсыз сүзләр, охшатулар бар.* М. Җәлил.

ОХШАУ *ф.* **1.** Охшаш булу. *Мал иясенә охшый.* Мәкаль. *Син охшыйсың күлдә йөзгән аккошларга, Йөргәнеңдә ак күлмәк, ак башмак белән.* Ш. Бабич. *Ялкын телләреннән аерылып киткән очкыннар, алтын күбәләкләргә охшап, агач башларына кундылар.* К. Нәҗми.

2. Юнәлеш килеш формасындагы билгесез үткән заман хикәя фигыльләр янында чамалап нәтиҗә ясауны белдерә: бугай, ахрысы. *Күптән түгел яңгыр яуганга охшый: юлда аз-аз җыелып тора торган сулар да күренгәли.* М. Гали. — *Бу малай чыгырыннан чыга башлаганга охшый.* Д. Аппакова.

Охшарга тырышу — эштә, кыланышларда һ. б. кемнең дә булса үрнәгенә иярергә тырышу. *Аның бер кулын һәрвакыт чалбар кесәсендә тотуында да кемгәдер охшарга тырышу сизелә иде.* Г. Бәширов.

ОХШАУЛЫ *с.* Охшаган, охшаш. *Төрмәгә охшаулы авыр, салмак, караңгы роман чиркәүләре готика чиркәүләренә алмаша барганнар.* Г. Гали. *Сахралардан сезгә охшаулы чәчәкләр таба алмадым.* Җыр.

ОХШАШ *с.* 1. Кем яки нәрсә белән (төс, кыланыш, эш, хәрәкәт һ. б. яклардан) якынлыгы булган; кем яки нәрсәне хәтерләткән; тиңдәш. *Яңа туган айга охшаш кашы аның.* Г. Тукай. *Бармы моңа охшаш кабахәтлек, Үтеп киткән ерак заманда?* Ш. Маннур.

2. *мат.* Зурлыклары төрле булып, формалары белән генә тиңдәш, бердәй. *Охшаш күпочмаклар. Охшаш өчпочмаклар үзлеге. Охшаш буыннарны берләштерү.*

ОХШАШЛАНДЫРУ *ф.* Нәрсәгә дә булса охшаш итү, охшаш ясау. *Бер тартык аваз үзеннән алда килгән тартык авазны охшашландырса, регрессив ассимиляция була.* Э. Әфләтунов.

ОХШАШЛАНУ *ф. сир.* Охшаш булып китү, охшашка әйләнү, бердәй үзлекләргә ия булу; *к.* охшау 1. *Охшашлану юлы белән синтаксик синонимнар ясалу.*

ОХШАШЛЫ *с.* Охшаш, охшашлыгы булган. *Менәменә хәтернең алгы ягында гына бу хатынга охшашлы сурәт тора.* Ф. Әмирхан. [*Насрый*] *бик әкрен генә иреннәре арасыннан сызгыртып, „Урман хикәясе"нә охшашлы бер көй тарта башлады.* Ш. Камал.

ОХШАШЛЫК *и.* Охшаш булу сыйфаты, бердәйлек. [*Тукайның „Теләнче" шигыре белән*] *Беранженың „Теләнче хатын" исемле шигыре арасында зур охшашлык булганын табу җиңел.* Г. Нигъмәти. *Соңгы вакытта Хәйрүшкә әллә нәрсә булды. Үзе белән аралашкан кешеләрдә Миләүшәгә охшашлык эзли.* М. Хәсәнов.

ОХШАШУ *ф.* Охшашлык булу, бер-берсенә охшау. *Янәшә яисә арадаш торган тартыкларның сөйләм процессында бер-берсенә тәэсир итеп охшашулары.* □ *Ниндидер бер охшашу аларны апалы-сеңелле итеп таныта иде.* Ф. Әмирхан.

ОЧ I *и.* 1. Нәрсәнең дә булса очлаебрак яки ныклаеп торган өлеше. *Бит очы. Борын очы. Яулык очы.* □ *Шәмси тез башына куеп кына, карандашының очын тешли-тешли, Нәсимәсенә кечтеки генә хат язып ташлады.* Г. Бәширов. *Ай-һай, аккош, матур кош, ике әйләп дә монда төш, Канат очыңа хат куям, җаныем кайда — шунда төш!* М. Фәйзи. *Зәйдүк билбавын сүтеп яңадан бәйләде, чабу очларын җыйнаштырды.* Г. Минский. || Нәрсәнең дә булса очлаеп, нечкәреп беткән югары өлеше. *Манара очы.* □ *Өйнең башында, кыек очында, әлбәттә, һәр яз карлыгач оя ясый, бала чыгара.* Г. Ибраһимов. *Мул дымлы күгелҗем болытлар агач очларына ук салынып төшәләр.* Р. Төхфәтуллин. || Сузынкы, озынча әйберләрнең бетем чиге, шул чик тирәсендәге өлеше. *Җеп очы. Дилбегә очы. Колга очы.* □ *Мулла, таяк очы белән бозлавык җиргә ныклаеп-бәреп, урам аркылы чыгып бара иде.* Ш. Камал. *Бүрәнәнең бер очында бар әчелгән ярыгы.* Г. Тукай.

2. Нәрсәнең дә булса (гадәттә шәһәрнең, авылның, урамның) уртадан, үзәктән ераклашкан ягы, чите, башы. *Түбәнге оч. Үрге оч. Бакчаның арты очы.* □ *Бармас идем мин шул очка, Җаным сөйгән шул очта.* Җыр. *Команда тавышы, казарманың бер очыннан икенче очына яңгырап, бөтен халыкның йокысын ачты.* К. Нәҗми.

3. *к.* очлык 1. *Чаңгы таякларына тимер оч кую.*

4. *күч.* Нәрсәнең дә булса асылы, нигезе. *Очы бик ерактарга яшерелгән җинаятьләрне ачуга бөтен яшьлек көчемне салып эшләдем.* Г. Бәширов. *Халисә бераз икеләнеп тә куйды, уйларының очын югалта язды.* С. Рафиков. || Башы, башлангычы. *Татар милли культура тармакларының зур бер өлешенең очы Каюм Насыйриға барып тоташса, икенче зур өлешенең очы, һичшиксез, Г. Камалга барып тоташа.* М. Гали.

5. *күч.* Нәрсәнең дә булса ахыры, бетүе, тәмамлану чиге. *Эшнең очы күренмәү.* □ *Безнең сызлану, кайгыруларның һичбер очы күренми.* М. Гафури. *Шушыдыр, — ди, — гомерем очы, Хәлемне үзем беләм.* Г. Хуҗи.

Очка җигү — җигемдә атны төпкә җигелгән аттан алда, башта бара торган итеп җигү. — *Чү, Закир, алай юк-бар өчен елап барма. --- [Алмачуарга] бернәрсә дә булмас, без аны буразна яклап очка гына җигәрбез.* Г. Ибраһимов.

◇ **Очы (килеп) чыгу** — берәр төрле эш-хәлнең ачыклануы, билгеле булуы, нинди дә булса нәтиҗә белән тәмамлануы турында. *Дүмәкләшә торгач, сугышның очы чыга ... Мәченең койрык очы өзелеп чыга.* А. Алиш. *Гөлчирә үзе барып әйтмәгәч, баланың батрачка икәнен белүче булмады. Ләкин моның очы килеп чыкмый калмады.* С. Рафиков. **Очы очка килмәү (ялганмау)** — ышандырырлык логик бәйләнеш, эзлеклелек булмау. [*Хикәянең*] *очы очка килеп бетми, шунлыктан ул бездә бераз шик тудыра.* Г. Гобәй. — *Сүзеңнең очы очка ялганмый. Син алдыйсың.* А. Расих. **Очын очка туры китерү (ялгау)** — 1) материаль яктан иркен яшәмәү турында. *Тормышның очын очка ялгап барам, артык мохтаҗлыгым юк иде.* Л. Ихсанова; 2) тиешле хәлгә, тәртипкә китерү. *Кооперативларда эшләүчеләр үзләренең чуалган эшләрен шомартырга, очны очка туры китерергә ашыктылар.* К. Нәҗми. **Очын (суга) яшерү** — 1) берәр төрле (ешрак: начар, җинаятьле, яшерен) эшнең эзен югалту; җинаятьне ачыкларга ярдәм итә торган билгеләрне юкка чыгару. [*Алпавыт малын*] *алып кайтып өләшергә дә очын суга!* И. Гази. *Ат аунаган җирдә төк калмый булмый инде. --- Эшли белеп эшләргә дә рәтләп очын яшерергә кирәк.* Г. Мөхәммәтшин; 2) ачык итеп әйтеп бетермәү (фикерне, сүзне). *Әйтәсе килгән сүзен коңгырт күзләреннән укып беләм, ул түгел. Ул бүген дә фикеренең очын суга яшерә.* Ф. Сәйфи-Казанлы. **Очына алып барып чыгу** — тәмамлау, башкарып чыгу, тулысынча хәл итү. [*Сәхап карт*], *ниятләгән эшен очына алып барып чыга алмыйча, тирәнтен хафаланып йөрде.* С. Рафиков. **Очына чыгарлык түгел** — 1) *к.* очы-кырые булмау; 2) буталган, ачыклавы бик кыен. **Очына чыгу** — 1) нәрсәне дә булса ачыклау, хәл итү, тиешле чаралар күрү. *Хәзер үк нидер эшләргә, ничек кенә булса да,* [*югалган*] *бодайның очына чыгарга кирәк иде.* Г. Бәширов; 2) *к.* очына алып барып чыгу. — *Мин бернәрсә уйлап йөрим. Очына чыгам мин аның.* А. Гыйләҗев; 3) аныклау, аныклы бер карарга, фикергә килү. *Ул авыр уйларның әле бер ягына, әле икенче ягына ташланды, ләкин очына чыга алмады.* Г. Ибраһимов. *Лейтенант Цветков та бу кызның кем булуын эченнән генә төрлечә юрап карады, ләкин очына чыга алмады.* Ф. Кәрим.

ОЧ II *и.* Эшләп чыгарганнан соң сату һ. б. ш. өчен төреп куелган зур гына кисәк, төргәк (тукыма турында). *Башланган оч ефәкне сатып бетерү.* □ *Оч-оч комачлар, бизәкле ситсылар --- күз явыңны алырлык булып янып торалар.* Ф. Хөсни. — *Хәбибә абыстайга бер оч киндер бирдем.* Г. Ильяси.

ОЧА *и.* Арка ягында билдән түбәнге урын, бот төпләре; арт сан (хайваннарда). [*Закир*] *атны аяклары белән бер кымтый, чыбыркы белән кабыргага, очага бер бирә дә дулатып, чаптырып китә.* Г. Ибраһимов.

Оча башы — умыртка сөягенең тоташып үскән биш умырткадан гыйбарәт һәм оча сөягенә килеп тоташкан түбәнге (койрык) өлеше. **Оча сөяге** — скелетның түбәнге (хайваннарда — арткы) очлыкларга тоташкан һәм умыртка сөягенә терәк булып торган өлеше (сөяк билбау); *русчасы:* таз.

ОЧА-КУНА *рәв.* Бик җитез, җиңел хәрәкәтләнеп. *Шатлык һәркемнең көлемсәр карашында, оча-куна йөрүләрендә сизелә.* С. Сабиров.

ОЧАН *и.* Балаларда була торган әч күбү авыруы.— *Бу баланың очаны калыккан, шуны имлим.* К. Нәҗми.

ОЧАНАК *с.* Бик тиз ярсып, кызып китә торган. *Сәфәргали - - - үзен шундый очанак характерлы атасына каршы китереп куйган икән, юк инде, моны үсмер чак бизгәге дип кенә калып булмый.* Ф. Хөсни. *Арсланның үз акылы үзе белән. Сәгыйдә кебек очанак түгел ул, сүзен үлчәп кенә сөйли.* Г. Ахунов.

ОЧАР: очар кош — 1) оча торган кош. *Очар кошлар җәйгелеккә җылы яклардан төньякка омтыла.* Ә. Маликов. — *Без йөргән җирләргә очар кош та барып җитә алмас.* Г. Ибраһимов; 2) *күч.* әш һәм яшәү урынын бик еш алмаштыручы; урыннан урынга күчеп йөрергә яратучы; *к.* очкалак 1. *Вәсилә [Варис яшәгән] бердәнбер бүлмәне күздән уздырды. — Мин шулайдыр дип уйлаган идем. Якуб абзый әйтмешли, очар кошка ярамаган тагын.* М. Хәсәнов. **Очар балык** — су өстенә сикереп чыгып, һавада бераз араны очып үтә ала торган балык.

ОЧЕРК *и.* 1. Реаль тормышта булган вакыйгаларны, анда катнашкан кешеләрне үзгәртмичә сурәтли торган кечкенә күләмле әдәби әсәр. *Бөтен сумка газеталардан кисеп алынган сугыш турындагы хикәя, очерклар белән тулы иде.* Г. Гобәй.

2. *күпл.* **очерклар.** Үзара бәйләнешле берничә мәсьәләгә караган тикшеренүләрне әченә алган махсус фәнни хезмәтнең исеме. *Татар теле буенча очерклар.*

ОЧКАК *с.* 1. Йомшак, мамык сыман. *Очкак кар.*

2. *и. бот.* Кайбер үсемлекләрдә җил белән җиңел очып таралу өчен канат сыман төкләре булган орлык.

ОЧКАЛАК *и. сир.* 1. Эш урынын бик еш алыштыра торган кеше; *русчасы:* летун.

2. Тик тормас, шаян холыклы кеше турында. *Бер заман минем янга Фирдәвес-очкалак йөгереп килеп җитте.* Ф. Хөсни.

ОЧКАЛАКЛЫ *с. бот.* Очып тарала торган. *Үсемлекнең очкалаклы орлыгы.*

ОЧКАЛАКЛЫК *и.* Очкалак булу сыйфаты. *Бер караганда, минем теге әкият сыман бер нәрсә дигәнем дә аның шул очкалаклыгыннан килеп туды бугай инде.* Ф. Хөсни.

ОЧКО *и.* 1. Спорт ярышларында куела торган бәяләрне исәпләү берәмлеге. || Футбол, хоккей, шахмат кебек уеннарда отыш күрсәткече (һәр җинү өчен 2 яки 1 очко бирелә).

2. *сөйл.* Комарлы карта уенының бер төре.

◇ **Очко бирү** — нинди дә булса эшне бик оста башкару турында. *Чегән каракларына очко бирә иде ул ат белән кәсеп итү эшендә.* М. Әмир.

ОЧКЫЛЫК *и.* Күкрәк пәрдәсенең кысылуы сәбәпле иректән кинәт тын алу хәрәкәте; шундый хәрәкәт вакытында бугаздан кысылып чыккан өзек-өзек тавыш. *Күрше Вил абый куркытып карый, очкылыгым бары-бер бетми.* А. Гыйләҗев.

Очкылык тоту — күкрәк пәрдәсенең кинәт кысылуы аркасында иректән өзек-өзек чырылдык тавышлар чыгу. *Очкылык тотса, төшер исеңә, Мин булырмын сине сагынган.* Җыр. *Габдрахман, каенише Габдулланы күрү белән, телдән кала, аны очкылык тота башлый.* Ә. Фәйзи. **Очкылык үләне** *бот.* — әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан терлек ашамый торган үлән үсемлек; кыркырый; *русчасы:* икотник.

ОЧКЫН *и.* 1. Янып торган яки бик нык кызган матдәнең чәчелеп, таралып, очып киткән вак кисәкчеге; чаткы. *Очкыннан ялкын кабыныр.* Мәкаль. *Сүнеп, каралып килгән күмерләр, кинәт кызарып, очкыннарын тирә-якка чәчеп яна башладылар.* Г. Гобәй. || Таш, тимер кебек каты әйберләр бер-беренә бәрелгәндә, ышкылганда чыга торган ут кисәкчеге, чаткысы. *Атларның тоякларыннан тачанкага балчык йомарламнары атыла, кайчак ялт итеп очкыннар чәчрәп китә.* Г. Бәширов. *Станокта корыч кырам, Очкыннар җем-җем итә.* З. Мансур.

2. *күч.* Нәрсәнең дә булса җемелдәп ялтырап торган кисәкчеге; ялтырап, җемелдәп торган нокта, елтыравык. *Күз алдымда зәңгәрле-яшелле очкыннар чәчелде.* Ә. Айдар. *Менә ут шарының җылымса яктысы алтын төсле ефәк канаты белән кинә кырларны, урман өсләрен сыйпап узды, куак яфракларында алмаз очкыннар чәчрәтте.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Берәр нәрсәнең (иҗади эш, сәләт, тереклек һ. б.) барлыкка килү билгесе, яралгысы. *Әнә шул вакыйгалардан, аннары — тышкы бер көтелмәгән этәрештән дип әйтимме — язылачак яңа әсәрнең очкыны туа.* Г. Ахунов. *Әминәнең җиңел гәүдәсе сыерлар арасында күздән югала. Ләкин аның ташлап киткән очкыны мине борчый башлады инде.* И. Гази.

4. Нәрсәнең дә булса чагылышы, тәэсире. *Бу әсәрендә Горький реализм юлына нык кергән, ләкин әле романтизм очкыннары сүнеп бетмәгән.* Г. Нигъмәти. *Башкаларны чорнап алган кебек, - - - сугыш очкыны аларны да читтә калдырмады.* Ф. Хөсни. || Нинди дә булса хис белдерү билгесе (күзләр турында). *Егетләрнең күзләрендә шатлыклы очкыннар кабынып китте.* Ә. Айдар. *Чынлап та, бу усал хатынның күзләрендә ачу очкыннары чагыла иде.* Г. Минский.

5. *күч.* Дәртле, ашкынучан, бик үткен, елдам кеше турында.— *Кыз түгел — очкын. Уңган да соң үзе. Үсеп җитсә, кылны кырыкка яра торган кыз булыр бу.* Д. Аппакова.

Очкын методы — электр очкыны ярдәмендә металл әйберләрне эшкәртү методы. **Очкын сүндергеч (тоткыч)** — паровоз, локомобиль һәм вагранкаларның төтен трубаларында очкын чәчрәп чыгуны тоткарлау өчен куелган махсус прибор.

ОЧКЫНЛАНУ *ф.* 1. Очкыннар (1 мәгъ.) чыгару, чәчү; очкыннар барлыкка китерү. *Учаклар очкынланып яну.*

2. Очкын (2 мәгъ.) сыман булып җемелдәү, ялтырау. *Кояшта чыклар очкынлану.* □ *Аяз төннең зәңгәр күгендә Очкынланып яна йолдызлар.* М. Җәлил.

3. *күч.* Көчле, интенсив рәвештә чагылыш табу; күренү, сизелү. *Габдулланы кызыксындырмаган бу партия, класс, социализм, демократия кебек сүзләр хәзер инде ниндидер якын мәгънәләр булып очкынлана, кабына башладылар.* Ә. Фәйзи. *Аерым-аерым шигырьләрдә очкынланган көчле шигъри җөмләләре белән бик күп яшь көчләр кинәт үзләренә дикъкатьне алалар.* Һ. Такташ.

4. *күч.* Нинди дә булса хисләр белдереп елтырау (күзләр турында). *Очкынлана яшьлек дәрте Зур кара күзләрендә.* Г. Хуҗиев. — *Әнә бит ул ничек бирелеп тыңлый, күзләре очкынлана.* А. Әхмәт.

ОЧКЫНЛАУ *ф. сир. к.* очкынлану 1. *Төтен сүнми, кыза, очкынлый, Ут тудыра, җиргә түшәлә.* Ә. Фәйзи.

ОЧКЫНЛЫ *с.* 1. Очкыннар (1 мәгъ.) чыгарып башкарыла торган. *Очкынлы кабызгыч.* □ *Очкынлы бушанулар газларда гына түгел, каты һәм сыек диэлектриклар эчендә дә булырга мөмкин.* Физика.

2. *күч.* Нинди дә булса хисләр белдерә торган (күзләр, караш турында). *Очкынлы караш.* □ *Хәятның күзләре бу, үзләренә якын ук тора торган*

сөйкемле йөз һәм очкынлы, уйчанрак карый торган коңгырт күзләргә төште. Ф. Әмирхан.

ОЧКЫР *с. диал.* Яхшы, җитез очучан. *Торымтайдай очкыр кош булмас, Тургай ташлап каз алмас.* Мәкаль.

ОЧКЫЧ *и.* Оча торган машина; самолет. — *Ярый, лейтенант. Хәзер барып очкычыгызны хәзерлгез.* Ш. Усманов. *Сәяхәт башлыгы — күк механикасы һәм космик очкычлар буенча белгеч кеше.* А. Тимергалин.

ОЧЛАЙТУ *ф.* Очлы итү, очлы формага китерү. *Кибәннең башын артык очлайту.* || Алга таба чыгару (иреннәр турында). *Гөлҗиһан авызын очлайтып шырпы сүндергәндә, Җәгъфәрнең бөтенләй диярлек хатынына ачуы сүрелгән иде.* А. Расих. *Данилов җавап бирергә ашыкмады, иреннәрен очлайтып, бик тәмләп суырды да тәмәке төпчеген Борисовка сузды.* Г. Бәширов.

ОЧЛАНДЫРУ *ф. к.* очлайту. [*Губернаторның*] *мыек очлары патшаныкына охшатып очландырып борылган.* Г. Минский. *Мулла чалма бүреген, очландырып, чикәсенә кырын салган.* Ш. Камал.

ОЧЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* очлау 1. *Очланган карандаш.* □ [*Җәзалаучылар*] *егетнең шомырт кебек күзләренә кылдан нечкә итеп очланган инәләр кададылар.* А. Алиш.

2. *к.* очлаю. *Аның йөзеннән кан качты; борыны очланып калды.* И. Гази. *Өй түбәсенә мендем дә, аның иң очланып килгән җиренә барып, кулларым белән моржага ябышып тора башладым.* Ф. Әмирхан.

3. *күч.* Бетү, тәмамлану. *Юл әҗгәмәсе балаларның киләчәкләре турындагы якты хыяллар белән очланды.* Г. Минский. *Контрреволюционерларның халыкка каршы эшләре котылгысыз рәвештә - - - җиңелү белән очланачак.* И. Нуруллин.

4. *күч.* Бер-бер артлы, очлап җигелү. *Бикмөхәммәт, Закир дигән малайларның, бәләкәй чанага очланып, мине урам буйлап йөртүләрен әле дә булса уйлап көләм.* М. Гафури.

ОЧЛАП I *рәв.* Оч-оч итеп, кисәге белән. *Очлап сату.*

ОЧЛАП II *рәв.* Бер-бер артлы (бер җигемдә берничә ат булганда). *Дүрт чана, алдагысына очлап ике ат җигелгән. Башкаларына берәр.* Г. Ибраһимов.

ОЧЛАУ *ф.* 1. Оч ясау, очлы итү. *Тимергали, кесәсеннән пәке чыгарып, карандашын очларга тотынды.* Ш. Мөхәммәдев. *Мәхмут, плитада кыздырып-кыздырып, кечкенә сандалда кәйлә очлый.* Ш. Камал. || Оч ясау, оч ишү (чыбыркыга). *Әхәт чыбыркысын очлап бетерә, торып шартлатып җибәрә.* Һ. Такташ.

2. Нәрсәнең дә булса (кибәннең, манараның, эскертнең һ. б.) югары, оч өлешен эшләү, ясау. *Чүмәлә очлау.* □ *Эскертне без кичкә очлап куйдык.* Н. Фәттах.

3. *күч.* Бетерү, тәмамлау. *Ул совхозда эшне очлаган да Ял итәргә килгән Кырымга.* М. Җәлил. *Нәфисә, сүзне тизрәк очларга теләп, иелә-бөгелә үлән нәр йолкыштырган дай итте.* Г. Бәширов.

4. *диал.* Төбәү, төзәү (мылтыкны, штыкны, сөңгене). *Озын Хөсәен, - - - штыгын алга очлап, якынаеп килгән солдатка атып җибәрде.* Һ. Такташ.

5. *күч. гади. с.* Әрәм-шәрәм итеп тотып бетерү, юкка чыгару. *Мал-мөлкәтне ике ел эчендә очлау.* || Һәлак итү. *Ул арада егерме беренче елның ачлыгы да килеп җитте... Тәмам бетереп, очлап куя язды ул безне.* Ә. Еники.

◊ **Очлап бару** — берәр төркемнең, колоннаның очында (иң ахырында) булу, очында (иң ахырында) бару. *Иң алдан ана бүре атлаганы күренә. Аның эзеннән — биелгы бала бүреләр. Карт ата бүре арттан очлап бар[а].* Г. Хәсәнов. **Очлап чыгу** — эшне ахырынача башкару, тәмамлау, эшләп бетерү. *Юньсезгә эш куш, үзең очлап чык.* Мәкаль. *Мин биел кичке мәктәпне очлап чыктым.* М. Маликова.

ОЧЛАШ: аяк очлаш *диал.* — аякларны каршы куеп (ятканда яки утырганда). *Алтмыш татар Аяк очлаш ятар.* Табышмак.

ОЧЛАШУ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* очлау (1, 2 мәгъ.).

2. *иск.* Җир кишәрлекләренең баш-башлары, очлары бер-берсенә терәлеп тору.

ОЧЛАЮ *ф.* Очлы форма алу, очлы булып чыгып тору. *Мәгыйшә түти, ак тышлы юрган ябынып, урын өстендә ята. Бите, суын сыгып алган лимон төсле, бөрешкән, борыны очлайган.* Г. Ахунов. *Бу озын түгел, әмма төбеннән биш чатлап ишелгән һәм бик очлаеп бетә торган кыска калын саплы чыбыркы иде.* Ә. Фәйзи. *Диңгезгә очлаеп кергән яшел кыя тагын да серлерәк бер төс алган.* Г. Әпсәләмов.

ОЧЛЫ *с.* 1. Очы (1 мәгъ.) нечкә, үткен булган; яхшы чәнчә, кадый торган. *Очлы без. Очлы сөңге. Очлы хәнҗәр.* □ *Вокзал түбәсеннән очлы бозлар асылынып төшкән иде.* Н. Фәттах. *Очлы, кытыршы ташларга, ниндидер тамырларга тотынып өскәрәк үрмәлим.* Р. Төхфәтуллин.

2. Очы (1 мәгъ.) чагыштырмача тараеп, нечкәребрәк беткән. *Очлы борын. Очлы бүрек. Очлы кибән.* □ *Ачык тәрәзәдән Миңнулланың очлы сакалы күренде.* И. Гази. *Пароходның очлы күкрәге белән сайга гөрселдәп керүе ишетелде.* Г. Гобәй.

Очлы яфрак — агулы кызыл җимешләре булган чәнечкеле яфраклы мәңге яшел куак яки кечкенә агач (медицинада кулланыла); *русчасы:* падуб. *Субтропиклар бик күп төрле үсемлекләргә бай. Биредә мәңге яшел үсемлекләрдән - - - очлы яфрак үсә.* СССР физ. геогр.

◊ **Очлы колак** — тиз һәм күпне ишетә торган кеше турында. *Безнең политрук — очлы колак — хәзер элеп алды: — Без, абыстай, Совет власте төзеп йөрибез.* К. Нәҗми. **Очлы күз** — 1) тиз күреп ала торган, үткен күз. *Шул вакыт Заһидулла агайның очлы күзләре йөгәнне күреп өлгерделәр.* Г. Галиев; 2) тиз күреп һәм аңлап алучан үткен кеше турында. *„Белеп, сораша, очлы күз!" — ди Хәбибуллин эченнән.* Ә. Еники. **Очлы күзле** — тиз күреп һәм аңлап алучан. *Очлы күзле егетләр дә минем ямансылап, эчтән сызып йөрүемне, күңелем урынында булмавын сизенделәр.* А. Тимергалин. **Очлы сүз** — үткен, усал, төртмәле сүз. [*Сәфәргалинең*] *теленә очлы-очлы сүзләр килә, ләкин шулай да тыелып кала, әйтми.* Ф. Хөсни. **Очлы тел (ле)** — тапкыр, үткен һәм чәнчеп сөйли торган кеше турында.

ОЧЛЫК *и.* 1. Нәрсәнең дә булса башына, очына кидерелә яки беркетеп куела торган очлы нәрсә (гадәттә металл кисәге). *Карандаш очлыгы. Сука очлыгы. Клизма очлыгы.*

2. *анат. күпл.* **очлыклар**. Кешедә — куллар, аяклар; хайваннарда — хәрәкәтләнү органнары. *Түбәнге очлыклар. Алгы очлыклар. Казу очлыклары.* □ *Җирдә шуышып йөрү гадәте аркасында, еланнарның очлыклары беткән.* Биология.

3 *к.* төпчек 2. *Күзгә ташланган өч-дүрт өстәл, иске урындыклар, идәндә чәчелеп яткан тәмәке очлыкларыннан башка* [*бүлмәдә*] *бернәрсә дә юк.* Ш. Камал.

ОЧЛЫКТЫРУ *ф. диал.* 1. Этеп, атып, ераккa җибәрү, очыру.

2. *күч.* Юкка чыгару, нәрсәне дә булса әйтмичә генә икенче урынга яшерү.

ОЧЛЫПЫЙ *с. диал.* Очлы формадагы. *Кәҗә бәтиедәй сикергәләнеп, шаярып барган мех киемле, очлыпый башлыклы Илгиз хәзер барлык дикъкатьне үзенә тартты.* А. Расих.

ОЧРАК *и.* 1. Булган хәл, вакыйга, мажара (гадәттә, көтелмәгән, уйланмаган). *Аучы тормышында булган очраклар.* □ *Без, шундый очракларны искә төшереп, сөйләшеп утырганда, көлә-көлә Хәмәй карт кайтып керде.* Х. Кәрим. || Күз алдында торган яки күреп үтелгән факт, мисал.

2. Нәрсә дә булса эшләргә мөмкинлек тудырган шарт, уңайлы, җайлы момент, форсат. *Мидхәт, мондый очрак килеп чыгуына куанып бетә алмыйча, Андрей эшләгән Норен заводына ашыкты.* Г. Минский. *Шул очрактан файдаланып, пионерлар - - - Ибрайны пионерга керергә өндиләр.* Г. Гобәй.

3. Көтелмәгәндә килеп чыккан хәл. *Кинәт ишек төбендә ахылдаган тавыш ишетелде, автоматларны кысыбрак тоттык, чөнки һәрбер очракка хәзер булу кирәк иде.* Ә. Айдар. [*Мусага*] *котылу юллары юк иде, сукыр бер очрак тартып чыгарды.* Ш. Маннур.

4. *бәйл. функ.у.-вак. килеш.* **очракта.** Хәлләрнең, эшләрнең торышын, барышын белдергәндә кулланыла. *Бу очракта үзен бик бәхетле санау.* □ *Билгеле, аларны мәхәббәт һәм өйләнешү мәсьәләләре дә кызыксындырырга мөмкин. Ләкин мондый очракта беренче планда ул нәрсәләр генә булырга тиеш түгел бит.* М. Җәлил.

ОЧРАКЛЫ *с.* 1. Көтелмәгәндә, һич уйламаганда булган, барлыкка килгән. *Очраклы бер вакыйга аркасында - - - чабышкы аты асраудан ул бөтенләйгә кул селки.* Г. Нигъмәти. — *Сез һәрбер очраклы хәлләргә хәзер булып торырга - - - тиешсез.* Ш. Камал. || Искәрмәстән, көтмәгәндә туры килгән, килеп чыккан, очраган. *Без ул тауның һәртөрле тискәре җилләрдән һәм очраклы кешеләрнең көнче карашларыннан яшерен, аулак җиренә урнаштык.* Ә. Еники. *Бөгелмәдән Газинур очраклы атка утырып кайтты.* Г. Әпсәләмов. || *рәв. мәгъ.* Искәрмәстән, көтмәгәндә, уйламаганда. *Башкорт егете Җомагыл Өметбаев партизаннар арасына очраклы гына килеп керде.* Г. Гобәй.

2. Вакыт-вакыт, сирәк кенә булгалап торган. — *Сез бу хәлне Шәриповның очраклы бер ялгышы, аның юмартлыгыннан килгән бернәрсә итеп карадыгыз.* Р. Ишморат.

3. Тиешле җирлексез, нигезсез, сәбәпсез барлыкка килгән. *Очраклы фактларга таяну.* □ [*Әсәрнең*] *төенләнеше һәм чишелеше очраклы аңлашылмаучылыкка корылган.* М. Җәлил. *Шәйхи мәзиннең үз улы Нәгыйм белән Хуҗа Насретдин күркәсе арасында чагыштырма ясавын да очраклы гына бер әйбер дип әйтеп булмый.* Ш. Камал. | *рәв. мәгъ. Элеграк очраклы күренгән танышлык үскәннән-үсә барды, үскән саен гадиләште.* Г. Минский.

4. *филос.* Очраклылыкка (2 мәгъ.) нигезләнгән. *К. А. Гельвеций - - - тормышыбыздагы вакыйгалар бик кечкенә очраклы күренешләр нәтиҗәсе, ди.* М. Абдрахманов.

◇ **Очраклы рәвештә** — бер дә уйламаганда, ниндидә булса башка бер эшкә бәйләнешле рәвештә генә. *Бу хәлне Вәлишин бүген генә, анда да очраклы рәвештә, - - - Галимулладан ишетеп кенә белде.* К. Нәҗми.

ОЧРАКЛЫЛЫК *и.* 1. Очраклы хәл. *Аны, ниндидер бер очраклылык аркасында, авыр яралы кызылармеецлар белән бергә шәһәрдән алып чыгып китәргә өлгермиләр.* А. Шамов.

2. *филос.* Нигезләре һәм сәбәпләре әйберләрнең, вакыйгаларның эчке бәйләнешләреннән, асылларыннан килеп чыкмаган күренеш, хәл. *Үсешнең төп юлын, тенденциясен зарурлык билгели. Очраклылык исә аны конкрет күренешләр белән баета, бизәкли һәм һәрвакыт зарурлыкның чагылу формасы була.* М. Абдрахманов.

ОЧРАТУ *ф.* 1. Кемне дә булса берәр җирдә туры китерү, күрү. *Еллар үтте, Үләр көннәремдә Очраттым мин аны тагын да.* Һ. Такташ. *Зал-салонда Садри - - - кырынырга хәзерләнеп йөргән Мансурны очратты.* Ш. Усманов. || Кирәклек буенча күрү, эзләп табу, кайда да булса туры китерү. *Ильяс абзый - - - Идел буена китте һәм шунда крушник булып калды. Сажидә апа аны ике барып бер очрата алмады.* Г. Гобәй. — *Рәхим абзыйны заводта очратуы бик кыен хәзер.* Р. Ишморат. || Кемгә-нәрсәгә тап булу, юлыгу; күрергә, белергә туры килү. *Карт шагыйрь - - - Габдулланы мактарга тотынды: — Бу яшендә шигырь әйтешә белгән шәкертне мин әле гомеремдә беренче тапкыр очратам.* Ә. Фәйзи. — *Син шәһәрдә тордың: китаплар укыгансың, акыллы кешеләр очраткансың.* И. Гази.

2. Эзләп табу, туры китерү. — *Шәһәрдә бу нигъмәтләрне имгә-томга да очрата алмыйсың.* Ш. Камал.

3. Уку, тикшеренү, күзәтү, карау вакытында һ. б. ш. процессларда күрү, искәрү, ачыклау, белү. *Журналда Г. Камал тарафыннан ясалган гажәп уңышлы карикатуралар очратырга мөмкин.* М. Гали. *Бу кечкенә киоск янында бик күп кешеләрне, бик күп характерларны очратасың.* А. Шамов.

ОЧРАУ *ф.* 1. Барганда, кая да булса хәрәкәт иткәндә, кемгә яки нәрсәгә каршы булу, туры килү. *Юлда солдатлар бик күп очрый башлагач, бөтенләй юлсыз җирдән Җиде чишмә кыры буйлап китәргә туры килде.* К. Нәҗми. *Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышына уянып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле җилфердәшиләр.* Ә. Еники. || Кем яки нәрсәгә тап булу, туры килү, юлыгу. *Безнең гомер бөек планетаның Шау-шулы бер чорына очрады.* Һ. Такташ. || Кая, нәрсә янына барып чыгу. *Таштан ташка бәрелеп, шаулап агып яткан ялгага очрадык.* М. Гафури. *Күчәрбай ничек итеп тауга менүебезне, менгән вакытта саескан оясына очравызны - - - көлдерә-көлдерә сөйләде.* М. Әмир.

2. Нинди дә булса хәлгә дучар булу, нәрсә дә булса кичерү. *Авырлыкка очрау. Уңышсызлыкка очрау. Күңелсезлеккә очрау.* □ *Моннан ун ел элек Мохтар торган йорт танымаслык дәрәҗәдә зур үзгәрешләргә очраган.* Ш. Камал. || Нинди дә булса хәлгә эләгү, тап булу. *Буранга очрау.* □ *Һавадагы карга, давылга очраган күбәләктәй, арлы-бирле талпына да, канатларын җыеп, таш кебек җиргә таба омтыла.* И. Гази. — *Бөркет тавын кичкәндә бозлы яңгырга очрадык.* Т. Гыйззәт.

3. Табылу, булу. [*Җамали:*] *Белмим, кайчан очрар инде* [*кызның*] *миңа да ошаганы, мине дә ошатканы.* А. Әхмәт. *Кайдан килгән бу абзыйга мондый сирәк очрый торган саф, көчле калын тавыш?!* Ә. Еники.

4. Уку, тикшеренү, күзәтү вакытында һ. б. процессларда күренү, табылу, килеп чыгу. *Гомумән либреттоның теле әйбәт. Сирәк-сирәк кенә уңышсыз фразалар, сүзләр очрый, аларны төзәтергә мөмкин.* М. Җәлил. *Революциягә кадәр - - - хәтта Г. Камалның аерым әсәрләренә карата булган вак рецензияләр дә матбугатта бик сирәк очрый.* М. Гали.

◇ **Очраган бер кеше, очраган берсе** — теләсә кем, һәркем; туры килгән һәрберсе. *Очраган бер кешене,*

дошман күреп, һәлак итү фикерендә — җитсә көче. М. Гафури. *Очраган берсе яңа мөгаллимне ачык кына сәламли иде.* Ш. Камал.

ОЧРАШЛЫ *с. диал.* Очрый торган, була торган. *Сирәк очрашлы әйбер кадерле була бит ул.* И. Рәмиев.

ОЧРАШТЫРУ *ф.* 1. Очрашырга, күрешергә мөмкинлек бирү. *Ә шулай да язмыш — шаян ләгънәт, Очраштырды тагын аларны.* Н. Исәнбәт.

2. Вакыт-вакыт, сирәк-мирәк очрау; очраштыргалау. *Кешеләр күренми. Бары тик котелок белән иртәнге аш алып кайтучы солдатлар гына очраштырып куя.* Г. Гобәй.

ОЧРАШУ *ф.* 1. Кара-каршы очрау, туры килешү, юлыгышу. *Якуб трамвайдан сикереп төште һәм кинәт йөзгә-йөз Столяров белән очрашты.* И. Гази. *Көтмәгәндә булды бу очрашу.* Г. Хуҗиев. || Җансыз әйбер турында: бер-берсенә якынаю, кушылу. *Тау белән тау гына очрашмый, кеше белән кеше очраша.* Мәкаль. *Озакламый Идел, ашкынып, Яңа юллар белән очрашыр.* Ә. Ерикәй. || Бер-береннең күзләренә карау (*күз, караш* сүзләре янында). [*Аларның*] *күз карашлары ничектер очраштылар, шунда иреннәре юлыгышып киттe.* Г. Ибраһимов. *Хәйдәр белән күзләре очрашуга, Нәфисә нигәдер уңайсызланды.* Г. Бәширов.

2. Күнел ачу өчен күрешү, берҙә булу, бергә вакыт үткәрү. *Таң атканда, салкын чишмә буенда Очраштык без иркәм белән тагын да.* Җыр. *Икенче очрашуыбызда мин сиңнән кем булуыңны сорадым.* Г. Кутуй.

3. Нинди дә булса максат белән, кемнең дә булса килү уңае белән вакытлыча бергә булу, җыелу. *Очрашу кичәсе. Халыкара очрашу. Ватан сугышы геройлары белән очрашу.* □ *Язучылар союзы - - - язучыларның С. Сәйдәшев, А. Ключарев кебек аерым композиторлар белән очрашуын үткәрде, аларның иҗатлары белән таныштырды.* М. Җәлил.

4. *спорт.* Кара-каршы уйнау, ярышу, көч сынашу (футбол, хоккей, шахмат, бокс һ. б. ш. уеннарда). *Профсоюзлар спорт җәмгыяте һәм „Хезмәт резервлары" җәмгыятенең кызлар командалары очрашуы белән Татарстан беренчелегенә волейболчылар ярышы башланды.* Соц. Тат.

ОЧСЫЗ I *с.* 1. Очы ашалган, калынайган, тупа. *Очсыз карандаш. Очсыз без.*

2. *күч.* Чиге булмаган, чиксез. *Очсыз бушлык. Очсыз киңлек.* □ *Очсыз уйлар төрле якка тараладылар, ләкин ышанычлы бернәрсәгә дә барып тукталый алмадылар.* Ф. Кәрим.

ОЧСЫЗ II *с. сөйл.* Арзан, кыйммәт түгел. *Очсыз бәя. Очсыз товарлар.* □ *Эштән риза түгел идек: хак очсыз, акча арттырып булмый.* Ш. Камал. | *рәв. мәгъ. Алманы Казан байларына сатарга кирәк. Малик бик очсыз ала.* И. Гази.

ОЧСЫЗ-КЫРЫЙСЫЗ *с.* 1. Чиксез, чиге булмаган. *Очсыз-кырыйсыз дала. Очсыз-кырыйсыз диңгез.* □ *Күктә ни булмас, дисең, Очсыз-кырыйсыз күк бит ул.* Г. Тукай. *Крестьяннар, очсыз-кырыйсыз киң болыннарга тезелеп, печән чабалар.* Г. Гали. || Бер башыннан икенче башына кадәр бик озынга сузылган. *Очсыз-кырыйсыз чират.* □ *Ал байраклар, үз артларына очсыз-кырыйсыз батальоннарны ияртеп, урамның буена тезелделәр.* К. Нәҗми.

2. Бик күп санлы, бихисап, санап бетергесез. *Очсыз-кырыйсыз маллар көтүе. Очсыз-кырыйсыз йолдызлар дөньясы.*

3. Чиксез күп, әллә никадәр. *Аның башына әллә ниткән очсыз-кырыйсыз борчулы уйлар килә.* Ф. Хөсни. *Тыштан ишетелгән авыр-авыр диңгез уфылдаулары караңгы өй эчендә, әллә нинди моңсу бер аһаң белән, очсыз-кырыйсыз дәрт һәм хыяллар көйли.* Ш. Камал. || *рәв. мәгъ.* Туктаусыз, өзлексез рәвештә. *Эч пошты, очсыз-кырыйсыз пошты.* Ф. Әмирхан.

ОЧСЫЗЛАНУ *ф. сөйл.* 1. Арзанлану, бәясе төшү. *Базарда ит һәм сөт азыклары очсызлану.*

2. *күч.* Вакланү; дәрәҗәне, абруйны төшерү.

ОЧСЫЗЛЫ *с.* 1. *сөйл.* Арзанлы. *Киеменең очсызлы булуына карамыйчан, керсез, тузансыз булуы - - - бу татарны миңа сөекле күрсәтте.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Мәгънәсез, буш, берниндә әһәмияте булмаган. *Очсызлы эффектларга бирелү.*

ОЧСЫЗЛЫК *и. сөйл.* Арзанчылык. *Базарда быел очсызлык.*

ОЧТАШ *и.* 1. Кем белән дә булса бер очта (2 мәгъ.) торучы.

2. Кем белән дә булса җир, кишәрлек башлары эргәдәш булган кеше.

ОЧУ *ф.* 1. Һавада канатлар ярдәмендә хәрәкәт итү. *Акчарлаклар оча уйнашып, Канатларын кагып суларга.* Ә. Исхак. *Чыпчык үзенең балачагын очарга өйрәтә.* И. Гази. || Күчеп китү (күчмә кошлар турында). *Мин күзәттем: көньягына быел Соңга калып очты торналар.* Ф. Кәрим.

2. Һавада, бушлыкта йөзеп йөрү, бер урыннан икенче урынга күчү, хәрәкәт итү (самолет, дирижабль, космик корабль кебек очкыч машиналар турында). *Дирижабльдә очу.* □ *Рус солдатлары белән немецлар арасында канлы бәрелешүләр бара. Һавада ике якның аэропланнары - - - бер-берен куып очалар.* Г. Ибраһимов. — *Озак та очмадык, куе томан, яңгыр болытлары безне чорнап ала башлады.* Т. Гыйззәт.

3. Җил яки ыргыту, ату көче белән һавада хәрәкәт итү, бер урыннан икенче урынга күчү. *Тузан очу. Кар очу. Снаряд очу.* □ *Бишбалта, Ягодная бистәләрен каплаган төтен эченнән, иләмсез тавыш белән гүләп, калай табаклары, такта кисәкләре оча.* К. Нәҗми. *Шаяхмәтнең колак төбендә безелдәп пулялар оча башлады.* А. Әхмәт. || Тирә-якка чәчрәү, таралу. *Очкыннар очу.* □ *Атлар очсыз-кырыйсыз киң дала буйлап чабалар. Ялларын җил тузгыта, авызларыннан канлы күбекләр оча.* Г. Әпсәләмов. *Шаулап оча йомычкалар, Нарат исе тарала.* Ә. Ерикәй.

4. Һавага таралып юкка чыгу (парга, газга һ. б. әйләнеп). *Ачы җил исә башлауга, томан күтәрелде, иртәнге чык тамчысы төсле, ул да китте, җилгә очты.* Г. Бәширов. *Без яшәгәндә ил булып, Дошман оча көл булып.* Ә. Фәйзи.

5. *күч.* Юкка чыгу, юк булу; качу, кая да булса китеп югалу, кайтмау. [*Шәйхезаман:*] *Табып китерегез миңа алдар Байтирәкне, башкорт Исәнбайны, кизү Миртимерне!* [*Бәхтияр:*] *Алар күптән очтылар инде. Хи-хи-хи.* Т. Гыйззәт. || Бетү, юкка чыгу (талану, урлану, алдану, әрәм-шәрәм ителү һ. б. ш. сәбәпләр аркасында). [*Гайни:*] *Вакытның күпме икәнен беләсең килсә, сәгатеңне кара.* [*Закир:*] *Бик карар идем дә, күптән очты шул инде ул.* Г. Камал. *Юлдашым - - - җир сатып алган акчадан соңгы тиеннәре дә очканын сизде булырга кирәк.* Г. Ибраһимов.

6. *күч.* Бетү, юкка чыгу, онытылу (нинди дә булса хис турында). *Кайчак ул сагышлана, әмма аның сагышы, иртәнге чык кебек, тиз оча иде.* Г. Әпсәләмов. || Тормышка ашмау, юкка чыгу (өмет, хыяллар турында). — *Их, нинди матур хыялларым бар иде бит минем! Бар да очты!* А. Алиш. — *Булмады,*

улым, — диде Галиулла, Хәлимне коҫагыннан чыгарды. — Бәхетең юк икән. - - - Хәтфә кәләпүшләр очтылар. И. Гази.

7. Бик кызу хәрәкәт итү, чабу, йөгерү. *Иң якын дусларымнан Һади белән Сафуанны иярттем дә, елга буена очтык.* Г. Галиев. *Айгырның сыртына бернә салган идем, атым дөлделдәй оча башлады.* Ә. Айдар. *Мотоцикл инде, кызны әләктереп, басу буйлап оча иде.* Ф. Хөсни.

8. *күч.* Бик тиз үтү (вакыт турында). *Ул заманнар инде ерак калды. Вакыт оча да оча.* Г. Хуҗи. *Оҫкын көннәр, очкындай яшьлегем - - - Очты китте, бик күп еллар үтте.* Ә. Ерикәй.

9. *күч. сөйл.* Эш урыныннан куылу, чыгарылу, төшерелү. *Карт, капка төпләрен пычрак тоткан өчен, күптән бу урыннан очкан.* С. Җәләл. — *Бик алай кылансаң, [председательлектән] ничек очканыңны сизми дә калырсың.* Г. Ибраһимов.

10. *күч.* Кая да булса омтылу, ашкыну (хыялда, күңелдә). *Уйларым ераста калган Казан тирәсенә очтылар.* Г. Бәширов. *Каз юлы буйлап очтылар Канатлы хыялларым.* Ф. Кәрим.

11. *күч.* Таралу, еракларга, күпләргә барып ишетелү, ирешү (дан, хәбәр, һ. б.). *Аның даны очадыр илдән илгә.* || Таралу, җәелү (моң, көй, җыр, тавыш һ. б. ш.). *Очтылар моңнар һавага, Җырлашып кызлар белән.* Ш. Бабич.

12. *рәв. мәгъ. күч.* **очып, очып-очып.** Усалланып, ыргылып, ярсып. *Хатын елый, малай дау куптара, Мин дә очып-очып талашам.* Ш. Маннур.

Очты, очты — уен (уен алып баручының, оча һәм очмый торган нәрсәләрнең исемнәрен аралаштырып әйтеп, „очты, очты“ дип кулын күтәргәндә, арадан бер яки берничә уйнаучының, ана ияреп, очмый торган нәрсәне әйткәндә дә ялгыш кулын күтәрүгә корылган). **Очу кыры** — аэродромда самолетлар очып китү һәм очып төшү өчен билгеләнгән мәйдан (гадәттә киң бетон юл). *Самолет йомшак кына итеп урынынан кузгалды да очу кырына юнәлде.* Каз. утл. **Очып бару** — 1) нинди дә булса юнәлештә очып хәрәкәт итү. *Кыр казлары очып баралар.* М. Җәлил; 2) самолетта кая да булса бару. *Марат инде әнисеннән әллә кайда ераста зур самолетта көнчыгышка таба очып бара иде.* Г. Гобәй. **Очып йөрү** — 1) бер тирәдәрәк дәвамлы рәвештә әйләнеп очу. *Сиваш турысында көтүе-көтүе белән киек казлар, торналар очып йөри.* Г. Бәширов. *Өстә, куркыныч улап, самолетлар очып йөри, алардан шәһәр өстенә бомбалар ява.* Г. Гобәй; 2) *күч.* җитез, җиңел хәрәкәт итү. *Күбәләк шикелле очып йөри иде ул [кыз] кичәләрдә.* А. Шамов. **Очып керү** — 1) кая да булса очкан хәлдә үтеп керү. *Ишектән һәм тәрәзәдән төрле төстәге күбәләкләр очып керәләр.* А. Әхмәт. *Немец авиациясе очып кергәч тә - - - шәһәрне, ярты сәгать эчендә, җир белән тигезләде дә куйды.* Ә. Еники; 2) *күч.* бик кызу рәвештә йөгереп, чабып килеп керү, килеп җитү. **Очып килү** — 1) очып, кая да булса килү, якынлашу, килеп туктау. *Камышлы күлдә, озак юллар очып килеп, бүген ач калган кыр үрдәге тынгысыз бакылдый.* Г. Гобәй. *Совет очучылары - - - боз тоткыннарын коткарырга очып килделәр.* А. Алиш; 2) *күч.* бик кызу чабып, йөгереп килү, кая да булса якынлашу. *Җир өстендә пар ат күренде. Мәгәр күз иярә торган түгел, - - - очып кына киләләр.* М. Шабай; 3) *күч.* бик тиз (чабып, йөгереп) барып килү. — *Минем атым йөгерегрәк. Хәзер очып киләм, — дип, ул атына атлана башлады.* Ш. Усманов. **Очып китү** — 1) очып ераклашу. *Казанка елгасы буендагы су тегермәне түбәсеннән күгәрченнәр очып киттеләр.* К. Нәҗми; 2) кая да булса юнәлү, бару (самолетта, вертолетта һ. б. ш.). *Самолетта очып китте иркәм ерак җирләргә.* Җыр. **Очып менү** — очып югарыга күтәрелү, кунаклау. *Күктә болыт әсәре күренә башлады исә, шул әтәч читән өстенә очып менә дә, канатларын җилпеп, кычкырырга тотына.* М. Гали. **Очып төшү** — 1) очу хәрәкәте белән түбәнгә, җиргә төшү, куну. *Күгәрченнәр очып төшә Ындыр арты бодайга.* Җыр; 2) *күч.* сикерү, сикереп төшү. *Малай, озын пиджак чабуларын канат итеп, күркә булып кагынды да [койма өстеннән] җиргә очып төште.* Г. Гобәй; 3) *күч.* кинәт атылып барып төшү, егылу. — [*Казакның*] *аты бер якка, үзе икенче якка очып төште.* Г. Минский. *Заһид, очып төшүдән курыккандай, куллары авыртырлык дәрәҗәдә кресло култыксаларына нык тотынып, шомлы минутлар кичерә башлады.* А. Расих; 4) *күч.* куылу, төшерелү (югары эш урыныннан). *Гыйльманов мастерлыктан алынды, ләкин директор үзе дә урынынан очып төште.* И. Гази. **Очып үтү** — нәрсә өстеннән яки нәрсә аша очкан хәлдә үтеп китү. *Баш очыннан ярканат очып үтте ашыгып.* Г. Гобәй. *Бу — Чкалов, Төньяк Котып аша Очып үтә Америкага.* Ф. Кәрим.

◇ **Очарга гына тору** — кая яки нәрсәгә дә булса ашыгу, ашкыну. — *Кызык халык бу кешеләр: менә инде очарга гына торалар.* Ш. Камал. **Очып куну** — 1) кискен хәрәкәт белән кемгә дә булса һөҗүм итү, ташлану. *Хәлил кинәт Исмәгыйльнең өстенә очып куна.* М. Фәйзи; 2) кемне дә булса бик нык гаепләү, ачулану турында. — *Минемчә, монда Җиһанша кордашка очып кунарлык урын юк, җәмәгать.* Ф. Хөсни.

ОЧУЧАН *с.* Очып парга, газга әйләнүчән. *Очучан сыеклыклар.* □ *Суган фитонцидларга — микробларны үтерә торган очучан матдәләргә бай.* Азат хатын.

ОЧУЧЫ *и.* Һавада оча торган машиналарны йөртүче. *Совет очучылары бөтен дөнья алдында беренчелеккә имтихан тоттылар.* А. Алиш. || *с. мәгъ.* Очучылар хәзерли торган. *Шамил очучылар мәктәбендә укый.* Т. Гыйззәт.

ОЧУЧЫЛЫК *и.* Һавада оча торган машиналарны йөртү эше, һөнәре. [*Җаббарның*] *очучылыкка һәм французча өйрәнүләре — бары мактауга лаек эшләр.* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Һавада оча торган машиналарны йөртүгә бәйләнешле. *Дх, мин әйтәм, әгәр Хөршидәм дә Очучылык эшен сайласа, Пар күгәрчен кебек очар идек Менә шушы иркен һавада!* З. Мансур.

ОЧЫ-БАШЫ: очы-башы булмау (күренмәү) — 1) бернәрсә дә билгеле булмау (берәр эш-хәл турында). [*Алтыннарның*] *очы-башы күренгәне юк.* Ш. Камал; 2) рәтсез, тәртипсез, буталчык булу турында. *Эшләгән эшенең очы-башы булмау.* **Очы-башы күренү (табылу)** — ачыклану, билгеле булу, хәл ителү (берәр эш, мәсьәлә турында). — *Айдар абыйның (проекты) ни эшләде? Әле очы-башы табылдымы?* Н. Исәнбәт.

ОЧЫК I *и.* Ашлык җилгәргәндә очкан чүп: кибәк, башак һ. б.

ОЧЫК II *и.* **1.** Боелыгын тота алмау авыруы, сидек тота алмау авыруы.

2. *сир.* Күзнең очлары кызарып, пешегеп авырту турында.

ОЧЫ-КЫРЫЕ: очы-кырые булмау (күренмәү) — 1) тозакка сузылган берәр эш-хәл турында әйтелә. *Әле сугышның очы-кырые күренми.* М. Мәһдиев; 2) берәр нәрсәнең күз күреме җитмәслек ераклыкка сузылган, җәелгән булуы турында. *Зәп-зәңгәр күк итәгенә барып тоташкан, очы-кырые күренмәгән бер кара урман бар.* А. Алиш. *Диңгезнең очы-кырые юк.*

Г. Нигъмәти; 3) чиксез күп булу турында. *Көзге болытлардай басып, каплап алган бу авыр, караңгы уйлардан ничек тә чыгарга, котылырга кирәк. Аларның очы-кырые булмас.* Ә. Еники. **Очына-кырыена чыга алмау (чыгарлык түгел)** — буталчык булу яисә аңлый алмау сәбәпле, нинди дә булса эшне башкарып чыга алмау турында.

ОЧЫНГЫЧ *с. сөйл.* Мактанчык, һаваланучан. *Бану --- миңа сөйкемле, иркә, ләкин очынгыч түгел, ә ягымлы булып күренде.* К. Басыйров. [*Сафуан абый*] *баянны тарткаларга тотынгач, минем авыздан шундый сүз ычкынды: — Алай уйнамыйлар, Сафуан абый. — Эй, син, очынгыч! Алай уйнамыйлар... Мин бит син түгел.* Ә. Баянов.

ОЧЫНДЫРУ *ф.* **1.** Җилфердәтү, тузгыту. [*Газинур*] *ак халат чабуларын очындырып йөрергә ярата.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Мактап масайту, һаваландыру.

3. *күч.* Дәртләндерү, ашкындыру, җилкендерү. *Разияның бер җылы сүзе Закирны тәмам очындырып җибәрә.* И. Гази. *Алсу үзенең бөтен эчке байлыгын уртаклашырга, аны очындырган барлык хисләрен сөйләп бирергә тели.* Х. Госман.

ОЧЫНУ *ф.* **1.** Үз алдына арлы-бирле очу, очып йөрү. *Акчарлаклар өермәгә эләккән яфраклар шикелле буталып очыналар.* Ш. Камал. *Киң канатлы ак, зәңгәр күбәләкләр, чәчәктән чәчәккә очынып, уйнашып йөриләр.* Г. Ибраһимов.

2. Канат кагу, җилпенү. *Карга чебеш ала, тавык очынып кала.* Мәкаль.

3. *күч.* Бик кызу, бик ашыгып, бик тиз бару, чабу. *Әле генә үз-үзләрен белешмичә очынган атлар шып туктадылар.* Ф. Әмирхан. || *рәв. мәгъ.* **очынып.** Атлыгып, бик җитез, җинел хәрәкәт белән. *Зәйнәпбану очынып килде дә байракны, тагын да күтәребрәк, чүмәләнең башына ук кадап куйды.* Г. Бәширов.

4. *күч.* Мактану, шапырыну; масаю. *Телгә килсә очынган, эшкә килсә кычынган.* Мәкаль. *Безне фронтка озаткан чакта: „Җиңгәнче сугышабыз!“ — дип, син очындың иң!* К. Нәҗми. [*Хәмит бай — Кайманга:*] *Абыстаң синнән зарлана. Син бик очынып киттең, эт малай.* Х. Садрый.

5. *күч.* Дәртләну, ашкыну. [*Зәйтүнәнең*] *рухи күзгалышын белмәгән кешеләр өчен бу һәрхәлдә аңлаешсыз бер очыну иде.* Ф. Хөсни. *Очынсам мин хисләр канатында, Үземә алам бәлаләр генә.* Х. Камалов. || *рәв. мәгъ. Бу җырларны җырлый безнең эшче Йөрәксенеп һәм дә очынып.* М. Гафури.

6. *күч.* Нинди дә булса хис белдереп, текәлеп карау (күзләр турында). *Айтуган картның үткен күзләре, --- ачулы елтырап, әле җыелышка, әле сакал очын тарткалап борчылып торган Тимеригә очындылар.* Г. Бәширов. *Разияның күзләре йомшак кына очындылар, --- мине кадерләделәр, иркәләделәр.* Ф. Әмирхан.

7. *рәв. мәгъ. күч.* **очынып, очына-очына.** Усалланып, ярсып, ыргылып. *Урман артындагы авылда этләр дә өрмиләр очынып.* Г. Гобәй. — *Аерыгыз әле шуларны, — әтәчләр шикелле очынып ябышырга гына торалар.* И. Гази. *Степан --- очына-очына кычкырып карады.* М. Шабай.

ОЧЫНУЛЫ *с.* Ашкынулы, дәртле. *Минем шушы очынулы сүзләремне* [*Гафури*] *башкалар шикелле үк тыныч кына, әмма игътибар белән тыңлап утыр* [*ды*]. З. Бәшири.

ОЧЫРГЫЧ *и. к.* очырткыч. [*Язгы җил*] *кәгазь очыргычларны һавада уйнатып йөртә.* С. Җәләл.

ОЧЫРМА *и. к.* чорма. *Очырмада коем бар, Ике төрле суым бар.* Табышмак. — *Нәрсә син анда очырмада кайнашасың өскә балчык коеп? Яшергән хәзинән бармы әллә анда?* К. Нәҗми.

ОЧЫРТКЫЧ *и.* Кәгазь яки тукыма ябыштырылган җинел агач киергедән гыйбарәт һәм озын җеп белән һавага җибәрелә торган балалар уенчыгы. *Балалар* [*һавага*] *җибәргән кәгазь очырткыч --- җирдән аз гына күтәрелеп очкан күбәләкне күр* [*де*]. Г. Тукай. — *Без очырткыч ясыйк, — диде Володя хәйләкәр елмаеп.* Р. Төхфәтуллин.

ОЧЫРТУ *ф.* **1.** *к.* очыру (1, 2 мәгъ.). *Җил кайчакта, азгын юлчы төсле, --- Башакларны өзә, сындыра да Юл буенча илтә очыртып.* М. Җәлил. *Зәйдүк, шешәне кулына алып, уч төбе белән бөкесен сугып очыртты.* Г. Минский.

2. *Йөкл. юн. к.* очу 2. *Нәфисәне, якты ра башлау белән үк, самолетка утыртып очыртыгыз.* Г. Бәширов.

3. Очып йөрү өчен иреккә чыгару (йорт күгәрченнәрен). *Сәмигулланы да анасы илә бергә җибәрергә кирәк, барыбер монда да әтәч сугыштырудан, күгәрчен очыртудан башка эше юк.* Ш. Мөхәммәдев.

4. *сөйл.* Бик кызу йөртү. *Шофер машинасын очырта гына.* || *рәв. мәгъ.* **очыртып.** Бик кызу; бик ашыктырып, бик тиз генә. [*Ат*], *хуҗасының арбага менеп утыру белән ачы итеп сызгыруы булды, очыртып алып та китте.* М. Шабай. — *Мин сезне үземнең „Волга“ да очыртып илтеп куям.* И. Гази.

5. Бик кызу, җитез эшләү турында. *Байгышның --- таза беләкләре көлтәләрне йон очырткан шикелле очыртудан туктамый.* Ф. Сәйфи-Казанлы. || *сөйл.* Ашыгып уку, сөйләү турында.

6. *күч. сөйл.* Ялганлау, арттырып, күпертеп сөйләү. — *Очыртасыз да Закир әфәнде. ---* [*Клиентлар*] *сездән ишетмичә дә фирманы беләләр.* Ф. Әмирхан.

◇ **Очыртып мактау** — *к.* күккә күтәреп мактау. *Захар Петровичның Ксенья Петровнаны, шундый шәп врач дип, очыртып мактавы --- Камилне өметләндереп җибәрде.* М. Әмир.

ОЧЫРУ *ф.* **1.** Очып китәргә мөмкинлек бирү, мәҗбүр итү. *Кошларны куркытып очыру.* □ *Һавадагы торнага ышанып, кулыңдагы чыпчыкны очырма.* Мәкаль.

2. Һавага күтәреп хәрәкәт иттерү (җил көче белән). *Очырырга җил көчле, Очыртмаска ир көчле.* Мәкаль. *Очыра-очыра юлның тузаннарын, Җилеп барды җиңел машина.* Ш. Мөдәррис.

3. Кошларның балаларын очарга өйрәтүләре турында. *Юл читендәге чирәм араларында чыпчык балалары чыелдаша — чыпчыклар бала очыра иделәр.* Г. Гобәй. *Кыр казлары бала очырганда, --- Кавышканнар алар тагын да.* Ш. Маннур.

4. Берәр нәрсәне көчле селтәнеп ату, ыргыту, чөю. *Апуш тагы балчык йомарлый да, баш өстебездән очып барган торналарга төзәп, һавага очыра.* Г. Ибраһимов. || Көч белән (тибеп, сугып, селтәп) читкә атылдыру, мәтәлдерү, тәгәрәтү. *Тибеп очыру.* □ *Мин икенче кулыннан барып тотарга өлгермәдем, башкорт --- Гаязны селтәп очырды.* М. Әмир.

5. *күч. сөйл.* Эш урыныннан куу, куып чыгару. — *Иртәгә сине завучлыктан очырачаклар, ә берсекөнгә мәктәптән үк куачаклар.* А. Расих.

ОЧЫ-ЧИГЕ: очы-чиге булмау (күренмәү) — 1) чиксез күп булу турында; 2) хисләрнең гадәттән тыш көчле булуы турында. *Ул аны сөядер иде, сөюенең очы-чиге юк иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ОЧЫШ *и.* **1.** Нәрсәнең дә булса очу, һавада бер урыннан икенче урынга күчү хәрәкәте. *Снарядның очыш ераклыгы.* □ *Урдәк очышын турылатырга тырышты, ләкин булдыра алмады, сыңар канатын*

җилпи-җилпи тагын да ярга барып төште. Мәр. Рафиков. || Авиациядә, космонавтикада: очу рейсы. *Космик очыш.* □ *Авиаполкта ике тапкыр орден алган герой штурман капитан Гали Борһан хезмәт итә. Ул 118 тапкыр хәрби очыш ясаган.* М. Җәлил. *Бу аның соңгы мәртәбә сынау очышы икән.* Ә. Исхак.

2. Очу рәвеше, манерасы. *Күгәрченнәр очышын күзәтү.* □ *Нина ап-ак киемнән, йөрешләре акчарлак очышы сыман талгын да, омтылышлы да.* Ә. Маликов.

Очыш кыры — *к.* очу кыры.

ОШАК *и. диал. к.* әләк. *Ошак сөйләгәннең пычагы теленда.* Мәкаль.

ОШАКЛАУ *ф. диал. к.* әләкләү.

ОШАКЧЫ *и. диал. к.* әләкче. *Ошакчының ошак сөйләми торса, тел очы кычыта, ди.* Әйтем.

ОШАНКЫРАУ *ф. диал.* Беркадәр охшашлык булу, нәрсәгә дә булса тартым булу. *Бу кыяфәте белән ул хирург профессорга ошанкырый.* К. Нәҗми.

ОШАТУ *ф.* **1.** Хуплау, ярату; лаеклы, яраклы дип табу; күнелгә хуш килү. *[Ул] кызны чынлап ошатты.* Ә. Еники. *Җыелышны бик ошаттым. Чөнки артык сүз боткасы куерту булмады.* Ш. Камал.

2. Кемнең дә булса таләпләренә, зәвыкларына яраклы итү. *Репетицияләр таңга кадәр сузыла, артистлар, уеннарын режиссерга ошата алмыйча, манма тиргә баталар.* Г. Бәширов. || *рәв. мәгъ.* **ошатып.** Килештереп, ышандырырлык итеп. — *Ай ахмак, ошатыбрак алдый да алмыйсың.* М. Фәйзи.

3. *к.* охшату. *Бу хат ирләр язуына ошатып язылган.* Ф. Әмирхан. *Илсөяр бер тоткынны бөтенләй этисенә ошатты.* Г. Гобәй. *Кына гөлне, матур гөлне Сина ошатам мин аны.* Җыр.

ОШАУ *ф.* **1.** Кемдә дә булса уңай, яхшы тәэсир тудыру (калдыру); күнелгә хуш килү. *Бабасының һәрбер сөйләгән вакыйгасын тирән тойгы һәм образлы картиналар белән сөйләве Габделкәюмга бик ошады.* М. Гали. *Гафиятнең хатынына Хәлим бик ошады.* И. Гази. || Кызыксыну, рухи якынлыкка омтылу хисе тудыру (егет яки ир белән хатын-кыз арасындагы мөнәсәбәт турында). *Кайсы нәләт төшкән икән Фәйрүзәгә ошаган?! Фәйрүзәдән сөелү күк зур бәхетка очраган?!* М. Җәлил. *Күнелләремә ошадың, Гомерлек булсаң иде.* Җыр.

2. Кемнең дә булса таләпләренә, эчке теләкләренә, зәвыкларына яраү, яраклы булу. *Хәлим ипинең үзенә ошаганрак кисәген алдына алып куйды.* Г. Гобәй. *Рәүфә Сафага гына түгел, аларның барысына да ошарга, ярарга, хезмәт күрсәтергә тырышты.* А. Шамов. || Нәрсә дә булса эшләргә яратү, шуннан канәгатьлек, ләззәт табу. *Миңа конькида шуу ошый.*

3. *к.* охшау. *Бу җыен моңа кадәр була торган җыеннарга ошамаган иде.* М. Әмир. *Уртанчы улы белән дә Гайшә апай мактана. Абыйсына ошаган, дип, уйлап шатлана.* Ә. Исхак.

ОШАУЛЫ *с.* **1.** Ошый (1, 2 мәгъ.) торган, яхшы. *Күнелгә ошаулы булу.*

2. *к.* охшаулы. *Алма алсу, чия кызыл, син шуларга ошаулы.* Җыр. *Ул Гарифның күзенә карамый, барлык дикъкате белән җәрәхәткә су тигезмәскә тырыша, гөл чәчәгенә ошаулы иреннәре беленербеленмәс кенә тетри.* Ш. Камал.

ОШАШ *с. к.* охшаш. *Чынлап та, корып, саргаеп беткән яз чәчәген иң тәмле хуш исләр чыгарып торган чәчәккә әйләндерү — ошашы булмаган матурлык бит!* Г. Кутүй.

ОШАШЛЫ *с. к.* охшашлы. *Мин боларның тупаслыгына, аяз көндә кояшны күрә алмауга ошашлы сукырлыкларына хәйран калам.* Г. Ибраһимов.

ОШАШЛЫК *и. к.* охшашлык. *Алыйк „Безнең көннәр"дәге Шакир солдатны: моның белән „Кызыл чәчәкләр"дәге Гыйлажи арасында зур ошашлык бар.* Г. Нигъмәти.

ОШАШУ *ф. сөйл.* Бер-берсен яратышу. *Юк, бу егет белән кыз арасындагы гади ошашу гына түгел! Бу — кешене котылгысыз бер хәлгә куя торган рәхимсез һәм татлы бер нәрсә.* А. Расих.

ОШБУ *а. иск. к.* бу, шушы. *Дөньяда куркак булу иң зур яман, Хосусан, һич ярамас ошбу заман.* М. Гафури. *Бер-ике ай вакыт ошбу рәвештә кичте.* Ш. Мөхәммәдев.

ОЮ I *ф.* **1.** Изрәү, йокымсырау; йоклау хәленә житү. *Симез кеше утырган урынында оер.* Әйтем. *Утыра торгач, оеп киткәнмен.* Х. Кәрим. || *рәв. мәгъ.* **оеп.** Изрәп. *Альфред артык озак уйлана алмады. Тиздән оеп йокыга талды.* А. Расих.

2. Тып-тын булу, бөтенләй хәрәкәтсез калу. *Шәмсетдин, - - - оеп калган айлы төнне шыңгырдатып, урам буенча кычкырып китте.* Г. Бәширов. *Мәрьям аның күкрәгенә башын куйды, иренең йөрәк тибешен тыңлап, бер минут оеп торды, аннары башын күтәрде.* Г. Әпсәләмов. || *күч.* Йомылып яшәү, бернинди акыл эшчәнлеге күрсәтмәү турында. — *Әйе, әйе, берни эшләми, киләчәкне онытып, Җаек мәдрәсәсендә оеп ятуның бер чиге булырга тиеш иде.* Ә. Фәйзи. *Миңа көрәш кирәк иде, тыныч тормышта оерга минем җилкенчәк йөрәгем риза түгел иде.* М. Максуд.

3. Берәр нәрсәгә бирелеп, үз-үзеңне оныту; онытылу. *Моңлы татар көенә оеп утырган чал сакаллы картның йөзендә тирән шатлык балкыды.* Г. Бакиров. *[Әсрарның] әкият сөйләвен тынласаң — оеп китәсең.* Г. Әпсәләмов. *Әйдә, ул тик Юк-бар хыял белән оесын.* Ш. Мөдәррис.

4. Сиземлелеген югалту, хәрәкәтсезләнү (тән әгъзалары турында). *Куллар ою. Тән ою.* □ — *Аякларың оемадымы. Габдулла энекәш? Сузып утыр син аларны.* Ә. Фәйзи.

5. *иск.* Намазда имамга, муллага иярү турында. *Намаз укылып, муллага ою чылар уңга-сулга „әссәламогаләйкем, ярхәмәкөалла" ны әйтеп дога кылгач, мулла михрабтан мөнбәргә күчте.* Г. Минский. || *күч.* Эштә, хәрәкәттә кемгә яки нәрсәгә дә булса иярү, буйсыну, бәйле булу. *Заманга оемый хәлең юк.* Мәкаль. *Тимерче күмерчегә оер.* Мәкаль.

ОЮ II *ф.* Әчеп яки башка төрле реакцияләр аркасында куеру, оешу; куерык, койка сыман хәлгә килү (сыеклыклар турында). *Кан ою.* □ *Киң агач савыт тулы катык, тигезләнеп, бавыр кебек каты оеган, пычак белән кис тә ал!* Г. Ибраһимов.

ОЯ *и.* **1.** Кош-кортның, җәнлекләрнең яшыкланып яшәү, йомырка салу һәм бала чыгару өчен ясалган, җайлаштырылган яки кеше тарафыннан махсус эшләнгән урыны. *Сыерчык оясы. Каз оясы. Тиен оясы. Кырмыска оясы. Тычкан оясы.* □ *Карлыгач килде авылга Җәен торырга, Җайлырак урын эзләде Оя корырга.* С. Хәким. *Күбәләккәй гөлгә кунган, Гөлдә булгач оясы.* Җыр. *Койма буйлап тимер рәшәткәле куян оялары тезелеп киткән.* Э. Касыймов.

2. *күч.* Яшәгән, торган җир; гаилә, йорт. — *Менә шушы инде Гыймади абзыйның оясы.* И. Гази. *Һәрбер кошның үз оясы булган кебек, минем дә үземнең гаиләм, үземнең оям бар.* Г. Галиев.

3. *күч.* Явыз максатлар белән җыела, туплана торган яшерен урын, оешма. — *Эшне ярты юлда калдырмаска кирәк. Контрреволюция оясын бу төндә тимер кул белән туздырырга.* Ф. Сәйфи-Казанлы. — *Без [мәдрәсәне] фетнә оясына әйләндерүгә*

юл куймабыз. Ә. Фәйзи. || Дошман урнашкан урын яки ул яшәгән ил. *Җиңү ихтыяры җитәкләде, Без туздырдык дошман оясын.* Ә. Ерикәй. — *Шундый кечкенә отряд белән казак оясына кереп китү зур ялгышлык булыр.* Ш. Усманов.

4. *күч.* Эш-хезмәт урыны турында. *Билгеле, эшли белмәгән кеше унбиш елдан бирле бер ояда гына утыра алмас.* Ә. Еники.

5. Кем яки нәрсәләр бик күп тупланган, яшәгән, үскән урын. *Кандыр буе, ай, кара урман, Киек җәнлеккәйләр оясы.* К. Тинчурин. *Кырлар ала-кола ... чокыр-чакыр, чүп-чар, билчән, әрем оясы.* М. Гафури. || Бер тирәгә тупланып, укмашып үскән үсемлекләр төркеме. *Оясы-оясы белән гөмбәләр очрау.* □ *Тик бер оя шомырт, матурланып, Ап-ак чәчәк белән киенгән.* Ш. Маннур. *Утрауларга охшап, оя-оя булып үскән куаклар, --- киң болынлыкны уратып алган әрәмәлекләр күзгә ташлана.* М. Хәсәнов.

6. *лингв.* Бер тамырга яки бердәй мәгънәгә караган сүзләр төркеме. *Синонимик оялар.*

7. Нәрсәне дә булса урнаштыру, салу, хәрәкәтләндерү өчен махсус эшләнгән уенты, тишек һ. б. *Капка күчәре оясы.* □ *Вибраторлар гөрли, бетон массасы калтырый һәм рәхәтләнеп кенә үзенә бирелгән ояга кереп утыра, тыгызлана, ката.* А. Гыйләҗев. || Берәр нәрсәнең эчкә батып, чокырланып торган урыны. *Күз оясы. Буын сөяге оясы.*

8. *диал.* Үсемлекнең орлыгын туфракка чәчү, үрентесен утырту өчен чокырландырып куелган урын; үсенте тирәсендә шулай чокырланып калган урын. *Кыяр оясы.* □ *Суны кешеләр берөзлексез кәбестә, помидор ояларына, кыяр, чөгендер һәм кишер түтәлләренә юллап тордылар.* Ш. Камал.

9. Сугыш кырында: яшерен ут ноктaлары, пулеметтуплар урнашкан урын. *Дошман лагереннан — дот, дзотларыннан, яшерен пулемет, туп ояларыннан безгә каршы ут ачылды.* Ә. Айдар.

10. *күч.* Нәрсәнең дә булса чыганагы, киң таралган, хөкем сөргән җире. *Акчишмә суы --- ничә мең еллардан бирле, тирә-юнен сазландырып, бизгәк оясы булып ята.* К. Тинчурин. *Минем эшкә ярдәм итте Фәннәр академиясе, Илебезнең фән чишмәсе, Бөек фикер оясы.* М. Җәлил.

Оя итү — оялау. *Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын Оя итте минем сөйгән карлыгачым.* Г. Тукай. **Оя тавыгы** — 1) чеби чыгарырга утырган (яки инде чебиләре булган) тавык; 2) *күч.* йорт, бала турында гына кайгыртып яшәүче хатын-кыз.

◇ **Оя башы** — гаиләдә беренче туган бала. — *Өйдә бит минем яшь ярым малай, оя башы, имчәк баласы Петя бар.* Ф. Хөсни. **Ояга бәйләнмәгән** — гаиләгә, йортка бәйле түгел; буйдак, өйләнмәгән. *Фабрикада исә халык төрле җирдән җыелган, ояга бәйләнмәгән.* В. И. Ленин. **Оя кору** — 1) өйләнеп, йортлы, хуҗалыклы булу. *Әткәй --- җиреннән, малыннан әзрәк өлеш чыгарса, мин, туган илгә кайтып, үземә бер оя корыр идем.* Г. Ибраһимов; 2) берәр эшкә җайлы гына урнашу турында. *Ипташ Заһид Сафич, сез монда [кафедрада] үзегезгә җылы гына оя коргансыз.* А. Расих; 3) кем-нәрсә тирәсенә елышу. *Кайда ялган сөйләүче бар. Син бул, ипташ, аннан бик ныклап сак; һәрвакытта шулар арасында Оя кора шымчы-диверсант.* Ә. Исхак. **Оя тарату (түздыру)** — хуҗалыкны, малны таркату. [*Мәргубә:*] *Менә ул оя тараткучы. Ни сине, яхшыдан яман туган нәрсә!* К. Нәҗми. **Оя тибү** — *к.* оя кору 1. *Бу вакыт эчендә Хәйрулла берничә тапкыр оя тибеп тә карый. Ләкин беркайда да ныклап тамыр җәеп җибәрергә өлгерми.* С. Сабиров. **Оя төбе** — 1) кечкенә, шыксыз, соңга калып чыккан чебеш. *Чебиләр арасында оя төпләре генә начар була. Алар гына тиресне тибәргә тиз өйрәнә алмыйлар.* Г. Толымбай; 2) төпчек бала. — *Әнисе, сиңа әйтәм --- балалар ни хәлдә? ... Улымны яхшы кара ... Ул инде оя төбе.* С. Рафиков. **Оясы белән актару** — барлык гаилә, туган-тумачаларыннан каты үч алу. *Миннән качып котыла алмассыз. Буш вакытта оягыз белән актарырмын әле бер!* К. Нәҗми.

ОЯДАШ *с. лингв.* Бер оядан (6 мәгъ.), бер тамырдан булган. *Оядаш сүзләр.*

ОЯЛАП *рәв.* Оя-оя итеп, ояларга (7 мәгъ.) урнаштырып. *Оялап чәчү. Оялап утырту.* □ *Теземнәргә оялап-оялап орлык күмелде.* Ш. Мөдәррис.

ОЯЛАТУ *ф.* Ояларга, оя корырга мөмкинлек бирү. *Өй алдымда гөлбакча, сандугач оялатам; Оялатам, биздермимен, сагынам, сиздермимен.* Җыр.

ОЯЛАУ *ф.* 1. Оя ясап урнашу (шунда яшәү, бала чыгару). *Күл буендагы өянкеләр башына каргалар оялаган.* И. Гази. *Сыерларның чисталыгын да яхшы дип булмый, --- кайберләренең сыртларына укра да оялый башлаган.* Ә. Еники.

2 . *күч. сөйл.* Эшләү, яшәү, тору өчен кайда да булса урнашу, төпләнү. *Ишле бала-чага белән кулыаягы бәйләнмәгән яшь-җилкенчәк кая да булса читкә таярга, шәһәрдә ояларга чамалый.* С. Сабиров. || Мәкерле максат белән кая да булса урнашу, туплану; елышу. *Фәхри --- совхозга оялаган чит бәндәләрнең эштәге гаепләрен ачып сала тора иде.* Г. Нигъмәти. — *Безнең волость Советына меньшевиклар, эсерлар, милләтчеләр кереп оялаган.* И. Гази.

3. *лингв.* Оядаш, тамырдаш сүзләрне төп сүз мәкаләсе эченә туплау (мәсәлән, Даль сүзлегендә). *Сүзлектә сүзләрне оялау ысулы белән урнаштыру.*

ОЯ'ЛМЫЙЧА *рәв.* Оятсыз рәвештә, бер дә оялып тормыйча, әдәпсезләнеп. *Мескеннәрчә, тагын оялмыйча, Коллык богауларын киямсез?* Һ. Такташ. — *Оялмыйча, Гайния алдында нәрсәләр сөйләп утырганын кара.* Ф. Бурнаш.

ОЯЛТУ *ф.* 1. Нәрсә өчен дә булса шелтәләп, үкенү, оялу хисе тудыру. *Хатын тагын ныграк кабынды: Бер оялтты, сүкте, хурлады.* Ш. Маннур. — *Ачуланып карадык, оялтып карадык, юк! Кермәгәч, керми икән кешенең колагына.* Г. Бәширов.

2. Төрле комплиментлар әйтеп, шаяртып, көлеп, уңайсыз хәлдә калдыру. *Кеше, нигә сез шулкадәр миңа сокланып карыйсыз? Мине оялтасыз.* Ә. Еники. [*Газизәнә*] *хөрмәтсез итәргә, оялтырга берсенең дә күңеле бармый иде.* Ш. Камал.

ОЯЛУ *ф.* 1. Нәрсә дә булса эшләргә тартыну, кыймау, уңайсызлану. *Мин, бик куркып һәм оялып, самовар артынарак барып утырдым.* М. Гафури. *Кыз, оялып, башын түбән иде, куллары белән кофта итәген уарга тотынды.* А. Шамов.

2. Оят тойгысы кичерү, кемнең дә булса алдында оятлы булу. — *Гафифәдән шулкадәр оялдым, бөтенләй менә җир тишегенә керерлек булдым.* Г. Камал. *Теге кичне кызулык белән әйтеп ташлаган сүзләре өчен хәзер ул үзе дә ояла.* Г. Бәширов.

ОЯЛЧАН *с.* Үтә тыйнак, базымсыз, тартынучан; юкка-барга оялучан. *Оялчан хатын — шәһәр бәясе, оялчан ир — тәкә бәясе.* Мәкаль. *Мин оялчан, кимсенүчән идем, Шул киртәне җиңә белмәдем.* Х. Камалов.

2. Оялу билгеләрен чагылдырган. *Мәрхәбә --- акрын, оялчан тавыш белән: — Менә инде син, әткәй! Андый эшне мин кайдан белим?! — диде.* Г. Ибраһимов. *Мин Саррәгә --- оялчан, яшерен һәм кыскакыскә қараңлар белән генә қарап-қарап ала идем.*

Ф. Әмирхан. | *рәв. мәгъ. Хөсәен белән ул һәрвакыт ничектер оялчан елмаеп, күн буяулары сеңгән кулларына карап сөйләшә.* А. Расих.

ОЯЛЧАНЛАНУ *ф.* Оялчанлык күрсәтү. *Оялчанланып башны ию.* □ *Кәримә, мәхәббәте көчәйгән саен, Шакир янында оялчанлана, кыюсызлана бара.* М. Әмир.

ОЯЛЧАНЛЫК *и.* Оялчан булу сыйфаты. *Дөресен әйтергә кирәк, заманында Каргалы кызлары арасында бу горур тыйнаклык, бу гыйффәтле оялчанлык бик көчле иде.* С. Сүнчәләй. *Аның оялчанлыгы аска карап әкрен тавыш белән исәнләшүеннән сизелеп тора иде.* С. Рафиков.

ОЯЛЫ *с. сөйл.* Өйләнгән, гаилә тормышы белән яшәүче. *Ул инде күптән оялы.*

Оялы күз бәйләш — күзе бәйле көтүченең, сызык белән тирәләп алынган „оялар"дагы уенчыларның берсен табып, аны тану, исемен дөрес әйтә алуга корылган уен.

ОЯЛЫК *и.* Тавыклар йомырка салу өчен өсте ябык кечкенә әрҗә формасында эшләнгән махсус оя. [*Тавык фермасындагы*] *бишәр-алтышар катлы йортларга охшап торган оялыклар, почмакка сибелгән кабырчык, вак ташлар, кетәклектәге чисталык — һәммәсе Татьяна Родионовнаның күңеленә хуш килде.* С. Рафиков.

ОЯЛЫШ *и. сир.* Оялу билгесе. *Оялыш күздә, күрек авызда.* Мәкаль.

ОЯТ *и.* **1.** Берәр начарлык, гаеп эш эшләүне аңлаудан туган көчле уңайсызлану, үкенү хисе. *Мин оятымнан нишләргә белмичә кычкырып елап җибәрдем.* М. Гали. *Чигенергә инде чик куелды, Җитәр ... оят та кирәк.* Ф. Кәрим. || Хурлык, мәсхәрә. *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә, Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.* Г. Тукай. *Бабаларыгыз, дүрт йөз елдан бирле Русия дәүләтендә торып, һичбер сугышта үзләренә оят, йөзләренә каралык китергәннәре юктыр.* Ш. Мөхәммәдев. [*Лаля Шәрәфкә:*] *Мине, яңадан үз муеныңа атылырга мәҗбүр итеп, ике кат оят, йөз кат бәхетсезлек астында калдырма. Кит!* М. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Хурлыклы, әдәпсез. *Оят эш эшләү.*

2. *хәб. функ.* Бик уңайсыз, читен. *Их егетләр, илдә сыйфат өчен көрәш бара, оят язарга. Д сез, эшегезне рәтләп эшләмичә, брак чыгаргансыз базарга.* Һ. Такташ. *Оят булса да, әйтергә кирәк, быел, мәсәлән, уңыш алу планын үти алмадык.* Ә. Еники.

◇ **Оят белән алыш-бireш бетү** — *к.* оят качу. *Оят белән алыш-биреш беткән, дрсез күзләр яшен шикелле.* М. Җәлил. **Оят белү** — ояту, әдәп саклау. *— Иптәшләр! Оят белергә кирәк! Әллә сез аны хәлдән тайдырмакчы буласызмы?* Ш. Камал. **Оят качу** — оялмый башлау, оятсызга әйләнү. *Бер оят качкач кача инде, бара торгач,* [*Шәриф*] *бер дә оялмыйча гына теләнә башлады.* М. Гафури. **Оят качыру** — әдәпсезлек, тыйнаксызлык, тәрбиясезлек күрсәтү. *— Әнә,* [*Вәрәкыя*], *безнең бу илдә бит ачып, оят качырып йөрүне башлап шул чыгарды.* Н. Исәнбәт. **Оят килү** — *к.* оятка калу. *Әлбәттә, оят килерлек җирдә ---* [*Зыя*] *кубызын уйнатмый да, күрсәтми дә.* Г. Ибраһимов. **Оят китерү** — оятлы итү, бик уңайсыз хәлдә калдыру. — [*Галимә*] *бөтен нәсел-ыруга оят китерде.* М. Гафури. **Оят сату** — фахишәлек кылу. *Оят сатсак та, ач булдык без, Азган-тузган кызлар төсле.* Г. Тукай. **Оят сүз** — әйтергә оят булган, әдәпсез, әшәке сүз. *Халык бик озаклап көлде, тагын әллә нинди оят сүзләр кычкырдылар.* Г. Ибраһимов. **Оят өлеше** — кунаклар ашаганнан соң савыт төбендә калган ашамлык. *Оят өлеше табада калыр.* Мәкаль. **Оят җир** — күрсәтергә ярамый торган әгъза; гаурәт. *— Менә өс-баш тузды, оят җирләр күренә башлар инде тиздән.* И. Гази. **Оятка калдыру** — ышанычны, өметне акламау,кыен хәлдә калдыру. [*Нәфисә:*] *Кызларыма таянам, шәт оятка калдырмаслар.* Г. Бәширов. **Оятка калу** — начар эш сизелеп, гаеп эш эшләп оятлы булу, уңайсыз хәлгә калу. *Яман белән йөрдем — калдым оятка; Яхшы белән йөрдем — җиттем моратка.* Мәкаль. **Оятка көч (килү)** — хурлык; хурлыкка калу, хур булу. *Эшне эшләп чыксаң — эш, Эшләнмәсә — оятыңа көч.* Мәкаль. *— Әгәр кукуруз уңышы буенча районда беренче булып чыкмасак, --- оятыма көч килсен.* А. Расих. **Оятны оныту** — ояла белмәү. — *Ай-һай-һай! Кем өйрәтте сине? Оныткансың, малай, оятны да!* Ш. Маннур. **Ояттан ашау** — оялуны белмәү. *Бибкәй бит качкан икән, Оятыннан ашкан икән, Ябышып чыккан икән, Ах, нәләт суккан икән!* Ш. Маннур. **Ояты юк** — оятсыз. *Ояты юк сатлык юлбасарның Бүген менә йөзе ачылды.* Һ. Такташ. **Оятыма каршы** *кер. сүз.* — үзеңнең нинди дә булса кимчелегеңне, гаебеңне танып, үкенеч белдергәндә әйтелә. *Без бөек үсешне күрдек. Ләкин, оятыбызга каршы, ул үсешне бик аз җырлавыбызны сиздек.* Һ. Такташ. **(Кемнең) оятын оятлау** — кемнең дә булса әдәпсезлеге, гаебе өчен уңайсызлану, ояту. *Торна оятын оятлап, ябалак урман түренә качкан.* Мәкаль. *— Менә шулай инде алар, әти, — диде Гөлбәһар абыстай. Әтисе алдында улларының оятын оятлаган сымак итте.* М. Гали.

ОЯТЛЫ *с.* **1.** Ояты, намусы булган, ояла белә торган. *Оятлы кызарыр, оятсыз агарыр.* Мәкаль. || *рәв. мәгъ.* Уңайсыз, гаепле хәлдә. *Мәрфуга апа алдында мин үземне оятлы итеп сизә идем.* Ф. Әмирхан.

2. Хурлыклы, түбән. *Безнең илдә юк оятлы һәм кадерсез һичбер эш.* М. Җәлил. *Караклыктан да оятлы эш юк.* Н. Исәнбәт.

◇ **Оятлы булу** — хурлыклы, көлкеле хәлгә калу; хур булу. — *Кодагый, зинһар, гаеп итә күрмәсен, үземнең зиһенсезлегем белән бик зур оятлы булдым.* Г. Камал. **Оятлы итү** — хурлыклы, көлкеле хәлгә калдыру. — *Ай юньсезләр, әллә ниләр әйттереп оятлы итә яздыгыз бит.* М. Фәйзи.

ОЯТЛЫК *и. к.* оят өлеше. [*Кунаклар*] *бәләшне ашаганда мактап бетерә алмадылар, --- зур таба төбендә тик оятлык кына калдырдылар.* Г. Ибраһимов.

ОЯТСЫЗ *с.* Начар, гаепле һәм килешмәгән эшләрдән оялмый торган; үтә әдәпсез, тыйнаксыз. *И, оятсыз! Битсез! Син бу эшне эшләргә --- оялырга кирәк иде.* Г. Тукай. *Көрмәкләшү һәм оятсыз сүгенү тавышлары бер-берсе белән аралашты.* Ә. Фәйзи. || Оятсызлык билгеләре чагылган. *Оятсыз караш ташлау. Оятсыз елмаю.* □ *Аның --- әшәке итеп карый торган оятсыз күзләре Нәфисәне чиркандыра, Сәйфи исә, күзен тозландырып, һаман хихылдый иде.* Г. Бәширов.

◇ **Оятсыз рәвештә** — һич оялып тормыйча, күзгә карап. *Теге, Нәгыйм дигән кеше, җыелышта оятсыз рәвештә әллә нәрсәләр ялганлады.* Ш. Камал. **Оятсыз сүз** — әшәке сүз, сүгенү сүзе. *Теге яктан кемнәрнеңдер чынаяк чокырын чәкелдәтеп җырлаулары, оятсыз сүзләр аралаштырып, ярылганчы көлүләре ителә.* К. Нәҗми.

ОЯТСЫЗЛАНУ *ф.* Ояла белмәү, оят сакламау; оятсыз рәвештә эш итү. *Курманаев, бөтенләй оятсызланып, большевиклар өстенә пычрак ыргыта башлагач, Егоров дәшмичә түзә алмады.* И. Гази. *Минем --- аңар оятсызланырга аз гына да юл куйганым юк.* Ш. Камал.

ОЯТСЫЗЛА'РЧА *рәв.* Оятсыз рәвештә, оятсыз кешеләргә хас булганча. *Оятсызларча эш йөртү.*

ОЯТСЫЗЛЫК *и.* Оятсыз булу сыйфаты; үтә әдәпсезлек, тыйнаксызлык. *Оятсызлык йөз ерта.* Мәкаль. *Дошманның шушы оятсызлыгы һәм ерткычлыгы безнең егетләрне иң караңгы, иң газаплы уйларга төшерде.* Ә. Еники.

ОЯЧЫК *и.* Нәрсәдә дә булса кечкенә генә уенты, күзәнәк. *Кәрәз оячыгы.*

ОҖМАХ *и.* 1. Дини уйдырмаларда: үлгәч, диндар, тәкъва кешеләрнең җаннары бик рәхәт, күңелле яши торган урын; җәннәт. *Күршең аркылы оҗмахка кергәнче, туры тамугка керүең артык.* Мәкаль. — *Мин сине шундый аргамакларга атландырырмын, оҗмахта да андый атлар күрә алмассың.* К. Тинчурин.

2. *күч.* Хафасыз, тыныч, күңелле яшәү һәм ял итү яки эшләү шартлары булган бик тыныч, уңайлы, матур урын турында. *Алмаев, --- кесәсеннән газета алып, аны агач төбенә җәйде дә утырды. — Оҗмах икән сезнең монда, — диде.* И. Гази. || Рәхәтлек; иркен, мул, ирекле тормыш турында. *Яшь егетнең куйны — оҗмах, авызы — бал.* Җыр. *„Дөньялар оҗмах иде ул чакта", — диде Миңлебай.* Ш. Бабич.

Оҗмах кош(лар)ы — 1) чыпчыклар отрядыннан эссе якларда яши торган һәм бик матур ялтыравыклы йоннары, каурыйлары белән аерылып торган кошлар семьялыгы; *русчасы:* райские птицы. *Таш пулатлар керми минем төшләремә, Кызыктырмый алтын сарай, оҗмах кошы.* З. Мансур; 2) *күч.* гөнаһсыз сабый бала (үлгәч әйтелә); 3) *күч.* Үтә беркатлы, нәрсә әйтсәң, шуңар ышана торган, дөньядан хәбәрсез булган.

◇ **Оҗмах байлыгы** — оҗмахтагы (1 мәгъ.) кебек иксез-чиксез байлык.

ОҖМАҲЛЫ *с. дини.* Имештер, җаны алдан ук оҗмахка билгеләнгән. *Байлар үлсә, оҗмахлы икәнен хәерчеләр дә белә, фәкыйрьнекен ишаннар да белми.* Г. Тукай.

ОҢГЫ *и. диал.* Балта күзе, сап кидерә торган тишеге.

ОҢГЫЛЫ *с. диал.* Тишекле. *Оңгылы сөяк.*

ОҢГЫТ *и. иск. диал.* Мәче башлы ябалакның бер төре. *Ил яманы — маңгыт, кош яманы — оңгыт.* Мәкаль.

ОһО *ы.* Гаҗәпләнү, соклану хисе белдергәндә кулланыла. *Егет кызны таза кулларына күтәреп алды да: — Оһо, җиңел генә икәнсең үзең, — дип пышылдады.* Э. Касыймов. [*Кызлар*] *өстәлгә күз төшерү белән үк: — Оһо, эш зурга киткән икән. Хәер, зарар юк, егете чибәр, — диделәр.* Г. Кутуй. || Шелтәләү хисе белдергәндә кулланыла. — *Оһо! Әле син әдәпсезлек белән дә дус икәнсең. Әй болай, карап торырга, ярыйсы гына малай күренәсең.* Д. Аппакова.

П

П Татар алфавитында 16 нчы хәреф.

ПА *и. сәнг.* Биюдә, танецта аякларны үзенә бертөрле итеп басудан гыйбарәт булган ритмик хәрәкәт. *Яңа па үзләштерү.*

ПАВИАН *и.* Африкада һәм Гарәбстанда яши торган озынча танаулы, эре гәүдәле маймыл. *Танганьика белән Виктория күлләрен әйләндереп алган тауларда этләр сыман өрә торган эт башлы павианнар һәркайда да очрый.* Материклар географиясе.

ПАВИЛЬОН *и.* **1.** Бакчаларда, паркларда салына торган бизәкле җиңел корылма (гадәттә ял итү яки ашамлык-эчемлек сату урыны). *Читтәге павильоннарда сыра, кымыз, тәмле-томлы нәрсәләр саталар.* А. Расих.

2. Күргәзмә экспонатларын, кинога төшерү реквизитларын һ. б. урнаштыру өчен бизәкләп салынган бина. *Парижда --- [декоратив сәнгать күргәзмәсендә] СССРның да аерым павильон төзеп катнашуы мәгълум.* Г. Гали. *Татарстан, синең павильоның Мәгърур павильоннар сафында.* Ә. Ерикәй.

ПАДЕ- Француз теленнән кергән классик бию (танец) атамаларында кушма сүзнең „бию" мәгънәсендәге беренче кисәге, мәсәлән: **падекатр, падепатинер.** *Уртада пар-пар тезелешеп падеграс бииләр.* Г. Мөхәммәтшин. *Танго башланды. Аннан падеспань һәм яңадан вальс.* Ш. Хөсәенов.

ПАДИША, ПАДИШАҺ *и. юг.* Патша. *Бишкә [биш яшькә] кадәр һәрбер бала — падиша.* Мәкаль. *Көннәрдә бер көн бер падишаһ сунарга чыккан иде.* Дәрдмәнд.

ПАДИШАҺЕ (ПАТШАҺЕ)-ӘГЪЗАМ *и. иск.* Император, иң бөек, иң зур патша; рус императоры. *Рәкыйп мулла падишаһе-әгъзам император Николай хәзрәтләре һәм аның гаиләсе сәламәтлегенә дога укыгач, Шакир Габдушев --- халыкны падиша гаскәренә ярдәм итәргә чакырды.* Ә. Фәйзи. [*Революционерлар*] *патшаһе-әгъзам хәзрәтләренә тел тидергәннәр, байларны, муллаларны да хурлаганнар.* А. Расих.

ПАДИШАҺИ *с.* Иң зур патшаларга гына хас булган. *Падишаһи ихтыяр.*

ПАДИШАҺЛЫК *и. иск. к.* патшалык. *Ике йөз мең халкы булган мәмләкәтләр рәхәт-рәхәт падишаһлык итеп торалар.* Ш. Мөхәммәдев.

ПАЁК *и.* Билгеле бер срокка һәм билгеле бер күләмдә бирелә торган азык-төлек. *Айлык паёк.* □ *Мин, аларның сорауларын көтми, бүген генә алып кайткан паёк икмәгеннән бер кисәген суздым.* Һ. Такташ.

ПАЖ *и.* **1.** Урта гасырларда Көнбатыш Европа илләрендә сарай хадиме булып, берәр асылзадәгә хезмәт итүче дворян улы — үсмер яки егет. *Граф пажга сукмакчы була, ләкин ялгыш Фигарога кундыра.* М. Җәлил.

2. Иске Россиядә привилегияле хәрби училище (пажлар корпусы) шәкерте.

ПАЙ *и.* **1.** Җан башына, исәптәге берәмлек башына һ. б. бүлеп бирелгән өлеш. *Кәла [Кәлимулла] ата-анасын белми. --- Аның үз паена тигән җир белән авыл халкы файдалана һәм шуның өчен елына бер мәртәбә Кәлагә баштанаяк киендерә иде.* Ак юл. || *күч.* Бәхет, өлеш. *Үз паеңны ташлап кеше пае артыннан йөрмә.* Мәкаль.

2. Уртак чыгымга катнашучыларның шул чыгым суммасына керткән исәпле өлеше. *Мөрсәлимовларның кайбер эре предприятиеләрендә аның [Хәсәншаның] зур сумалы пайлары [барлыгы] яшерен түгел.* Ш. Камал. *Ярулла --- аталарыннан еш кына акча һәм күчтәнәч алып тора, бүгенге [сыйлануда] юача белән чиклəвек аның пае иде.* Ә. Фәйзи.

Пай салу — уртаклашып катнашырга теләүчеләрдән өлеш җыеп, кирәк кадәр акча һ. б. туплау. **Пайга керү** — күп акча таләп итә торган берәр эшкә (әйбер алуга, сәүдәгә һ. б.) берничә кеше уртаклашып керешү. *Байга кергәнче пайга кер.* Мәкаль.

ПАЙЛАШУ *ф.* Пайга кереп бүлешү, уртаклашу. *Ике эт бер сөякне пайлашмый.* Мәкаль.

ПАЙП *аваз иярт.* Казларның һәм бала казларның бергә йөргән вакыттагы характерлы авазын белдерә.

Пайп-пайп итү — шундый аваз чыгару.

ПАЙПЫЛДАУ *ф.* **1.** Пайп-пайп итү (казлар турында).

2. *күч.* Ялынып яки протест белдереп сөйләү, сүз әйтү. *Шулкадәр әйттем, шулкадәр пайпылдадым — китте дә барды.* Ә. Баянов.

ПАЙПАК *и. диал.* Киез оек. *Пайпак киеп йөрү.*

ПАЙПАКЛЫ: пайпаклы итек *диал.* Башы күн белән сабылган йомшак киез итек. [*Кешенең*] *аякларында башлары очланып күтәрелгән пайпаклы итекләр.* И. Салахов.

ПАЙТӘХЕТ *и. иск. к.* башкала. *Ике дәрвиш бер паласка сыяр, ике патша бер пайтәхеткә сыймас.* Мәкаль. *Батыргали агай --- Франциянең пайтәхете Париж --- икәнен бер француздан артык белмәсә дә, ким белмидер.* Ш. Мөхәммәдев.

ПАЙЧЫ *и.* Уртакка, пайга кергән кеше; пайга керү нигезендә төзелгән оешманың (мәсәлән, кооператив сәүдә оешмасының) члены. *Мине, иң яхшы пайчы дип, президиумга сайладылар. Кибет белән кызыксына дип, --- мәктәп сөйләделәр.* Г. Мөхәммәтшин.

ПАЙЧЫЛЫК *и.* Уртакка, пайга кереп эш итү күренеше. *Зарифулла агай --- күрше-күлән белән пайга кереп, [корбанга] тәкә я тана кебегрәген чалып килгән килүен, ә соңга табарак --- мондый пайчылыктан баш тарткан.* Г. Минский.

ПАКГАУЗ *и.* Килеп төшкән яки җибәрелә торган йөкләрне вакытлыча саклау өчен тимер юл станцияләрендә, портларда һ. б. урыннарда корылган склад. *Биек водокачка, озын пакгаузлар, станциянең аръягындагы вак-вак йортлар күренә.* Г. Әпсәләмов.

ПАКЕТ *и.* **1.** Кечкенә кәгазь яки полиэтилен капчык, янчык. *Александра Андреевна кулындагы сумкасыннан берничә пакет белән лимон, әфлисун,*

алма, конфет, печенье --- алып бирде. М. Гали. *Җимешләр пешкәч, аларны салып сату өчен пакетлар кирәк.* Г. Галиев. || Билгеле үлчәмдә азык-төлек һ. б. салынган янчык, капчык, төргәк (мәсәлән, сату максатлары өчен). *Ул [офицер] немецны кибеткә алып керә дә ике пакет он алып бирә.* Г. Гобәй.

2. *к.* конверт. *[Цензура әһелләре] Сәрби әбинең солдат углыннан килгән хатны ачып укыгач, аның пакетына --- егет тарафыннан үзенең сөйгән кызына язылган гыйшык хатын ялгыш салып җибәргәннәр.* Ш. Мөхәммәдев. || Махсус зур конверт. *Сиңа, --- дистәләрчә яңа шигырьләремне салып, ике симез пакет җибәргән идем.* М. Җәлил. || Рәсми хат салынган, махсус печатьләнгән конверт. *Бу пакетта минем Ямансаз авылындагы мәктәпкә укытучы булып билгеләнүем язылган.* К. Нәҗми.

ПАКЕТБОТ *и. иск.* Почта һәм пассажирлар йөртә торган диңгез судносы.

ПАКИЗӘ *с. иск.* 1. Чиста, керсез, пөхтә, пакь, таза. *Аның [авылның] шактый киң урамы буйлап тезелеп киткән --- йортлары --- пакизәләр.* Ф. Әмирхан.

2. Пакьлек, чисталык, сафлык сөюче. *Пакизә хатын. Пакизә бала.* □ *Кыз булсаң, пакизә бул.* Мәкаль.

3. *и. мәгъ.* Керсез күңелле, саф кеше. *Бичара кыз, тәҗрибәсез пакизә булдыгыннан, аның сүзләренә ышанган.* Шура.

ПАКИЗӘЛЕК *и. иск.* Пакизә, пакь булу сыйфаты. *Бу пакизәлек --- йорт эче пакизәлегенең йортның тышына чыгышы иде.* Ф. Әмирхан. *Хәдичә абыстай [Гайшәне] зур кызлар кеби киенергә вә пакизәлеккә гадәтләндерә иде.* З. Һади.

ПАКТ *и.* Бик әһәмиятле, мөһим халыкара договор. *Һөҗүм итешмәү турындагы пакт.* □ *Ике держава үзара дуслык пакты төзегәннәр дә аны өченче державадан сер итеп саклыйлар.* Ә. Фәйзи.

ПАКУС *и. сөйл.* Чабылган печән яки иген теземе. *Малик шәкертнең чапканын карый, пакус арасында үләннәр киселми калганын күреп: „Алай калдырып чапма, әнем, пакус араң ялт итеп торсын“, — ди.* Н. Исәнбәт.

ПАКЬ *с. кит.* 1. Саф, чиста, болганмаган, пычранмаган (сыеклыклар турында). *Сөттән ак, судан пакь.* Әйтем. || Чип-чиста итеп чистартылган, юылган, тазартылган, керсез. *Урын-җирең пакь, бүлмәң җыйнак булса, чынлап та күңелле була.* М. Галәү.

2. *күч.* Начар ниятләрдән яки начар хисләрдән азат, керсез, саф. *— Сезнең күзләрегездән гөнаһсыз җаныгыз, пакь йөрәгегез күренеп тора.* Ф. Әмирхан.

ПАКЬЛЕК *и. кит.* Пакь булу сыйфаты. *Кыскасы, өй эчендәге бөтен әйбердән пакьлек, сафлык аңкып тора.* А. Шамов. *Безнең җырларны бизәгән бер нәрсә — ул халыкның күңел пакьлеген, хисләр сафлыгын чагылдыру.* Н. Юзиев.

ПАКЬЛӘНДЕРҮ *ф. кит. к.* пакьләү. *Киемнәрне пакьләндерү.* □ *Бәлки ул ялкын [көчле хис] минем күңелемне пакьләндерәдер.* Г. Бәширов.

ПАКЬЛӘНҮ *ф. кит.* 1. Пакь булып китү, чистару. *Хәзрәт --- юылып пакьләнмәгән киемнәр сораргa тотынды.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Бозык хисләрдән, начар ниятләрдән һ. б. арыну. *Күңел пакьләнү. Вөҗдан пакьләнү.* □ *„Гөнаһыдан җаны, тәне пакьләнсен“, — дип, Үгезне янган утка да салдылар.* М. Гафури.

ПАКЬЛӘҮ *ф.* 1. Чистарту, тазарту; сафландыру, пычрактан арындыру. *Шәһбазны суга кертәбез, тәнен пычак белән кырып юабыз да, шулай пакьләп, яңа киемкидерәбез.* Г. Ибраһимов. *Үз баласын ул [песи] юа, пакьли, теле белән ялый.* Г. Тукай.

2. *күч.* Начарлыклардан, яки бозык уйлардан, хисләрдән, начар теләкләрдән арындыру. *Якты ирек көне килде, Дөнья йөзен пакьләде.* Г. Камал.

ПАЛ *и. диал.* Фараз, гипотеза; эш-хәрәкәт планы. **Палга керү** — эшкә ашарлык булу.

ПАЛАС *и.* Бик тыгыз итеп тукылган калын келәм. *Хәтфә палас.* □ *Яшел чирәмгә паласлар, киезләр җәеп, табын-табын кешеләр утырганнар.* Г. Ибраһимов. || Матурлап, бизәкләп тукылган, үрелгән чыпта. *Карт сәкегә җәелгән камыш палас өстенә уңайлабрак утырды.* А. Шамов.

ПАЛА'ТА *и.* 1. *тар.* Бик матур итеп бизәлгән сарай залы; бүлмәләре бик бай җиһазландырылган йорт. *Патша палатасы.*

2. Дәвалау йортларында (больницада, лазаретта һ. б.) аерым бүлмә. *Унсигез-унтугыз яшьләрдәге көләч йөзле дежур сестра палатага килеп керде.* Ә. Айдар.

3. *күч.* Кайбер илләрдә хөкүмәт органы (парламентның аерым бүлеге, киңәшү комиссиясе һ. б.). *Югарыгы палата. Түбәнге палата. Лордлар палатасы.* □ *СССРның Верховный Советы ике палатадан — Союз Советыннан һәм Милләтләр Советыннан тора.* СССР тарихы.

4. Дәүләт күләмендә яки билгеле бер өлкә өчен бердәнбер булган кайбер дәүләт учреждениеләренең исеме. *Китап палатасы. Суд палатасы.*

ПАЛАТАЛИЗА'ЦИЯ *и. лингв.* Тартык авазларны нечкәртеп әйтү.

ПАЛАТАЛЬ *с. лингв.* Нечкә әйтелешле (тартык авазлар турында).

ПАЛАТАЛЬЛӘШҮ *с. лингв.* Нечкә әйтелү; палатальгә әверелү.

ПАЛА'ТКА *и.* Казыкларга баулар белән тарттырылып куела торган тукыма яки тире-ярылардан гыйбарәт бүлган җиңел торак. *Солдатлар һәм түбән дәрәҗәле офицерлар салкын, юеш окопларда, блиндажларда, землянкаларда һәм палаткаларда кышладылар.* М. Гали. *Ял иттек без палаткалар корып, Җиләк җыйдык яшел аланда.* З. Мансур.

ПАЛАЧ *и.* 1. Үлемгә хөкем ителгәннәрне берәр корал яки җайланма (балта, дар һ. б.) белән үтереп торучы кеше, җәллад. *Палач җепнең икенче башын тартты да югары асылган Гәрәйнең аяк баскан урындыгын кинәт тибеп очырды.* Г. Ибраһимов.

2. *күч. кит.* Явыз, изүче, җәзалаучы кеше. *Семенов — урядник, авылда патша палачы.* Т. Гыйззәт. *Бетсен канечкеч палачлар! Яшәсен эшче-крестьян!* М. Гафури.

Палач балтасы — баш кисә торган махсус балта. *Патша приказы --- палач балталарын, урядник камчыларын искә төшерде.* Х. Кәрим.

ПАЛАЧЛЫК *и.* 1. Палач булу эше (шөгыле). *Егерме елга каторгага хөкем ителгән тоткын Тарбашев палачлык хезмәтен үти икән.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Явызларча җәзалау, асу-кисү күренеше, террор. *Көрәш мәйданына чыгарбыз, Чыгарбыз да җирдә кан коюга, Палачлыкка чикләр куярбыз.* Ш. Маннур.

ПАЛЕО- кайбер кушма сүзләрнең „борынгы заманнарга караган“ дигән мәгънәне белдергән беренче кисәге, мәсәлән: **палеоботаника, палеогеография, палеозоология.**

ПАЛЕОАЗИАТ: палеоазиат халыклары, палеоазиат телләре *и.* Төньяк Себер халыкларының (чукча, коряк, юкагир, нивх һ. б.) һәм шулар сөйләшкән телләрнең уртак атамасы.

ПАЛЕО'ГРАФ *и.* Палеография белгече.

ПАЛЕОГРА'ФИЯ *и.* Борынгы кулъязмаларның тышкы күренеше (кәгазе һ. б.) һәм графикасы (хәрефләре, язылу рәвеше һ. б.) турындагы фән.

ПАЛЕОЗАВР *и.* Борынгы заманнарда яшәгән гаять зур кәлтә елан.

ПАЛЕОЗОЙ *и.* Җирнең геологик тарихында архей һәм протерозой эраларыннан соңгы өченче эра. *Тереклек җир өстендәге барлык океаннарны билән алгач, палеозой эрасы, борынгы тереклек эрасы туа.* Үтк. зам. сәяхәт.

ПАЛЕОЛИТ *и.* Археологик чор — таш гасырының иң борынгы дәвере.

ПАЛЕОНТО'ЛОГ *и.* Палеонтология белгече. *Галим-палеонтолог булса, бу сөякләрнең бик борынгы заманнарда яшәгән хайванныкы икәнен әйтеп сурәтләр --- иде.* А. Тимергалин.

ПАЛЕОНТОЛО'ГИЯ *и.* Борынгы чорларда яшәп, үлеп беткән хайван һәм үсемлек төрләрен аларның казылдык сөяк-санакларына карап өйрәнә торган фән. *Кешенең килеп чыгуы турында иң ышанычлы мәгълүматларны палеонтология бирде.* Гомуми биология.

ПАЛЕ'ТКА *и.* Үтә күренмәле пластинкага төшерелгән масштаблы челтәр — кәгазьгә һ. б. басылган (мәсәлән, карталардагы) фигураларның мәйданын якынча билгеләү өчен кулланыла. *Палетка ярдәмендә мәйданнарны төгәл үлчәп булмый.* Геометрия.

ПАЛИ'ТРА *и.* 1. Рәсем ясаганда рәссамның эш өчен кирәкле буяуларын урнаштыра торган махсус тактасы, оялары булган фанер яки катыргы кисәге. *Үсемлек буяулары художник палитрасындагы буяулар җыелмасына да керәләр.* Робинзон әзл.

2. *күч. җый.* Рәссамның кул астында булган барлык буяу төсләре турында. *Көзнең барлык яме, чуарлыгы Палитрага сыймый, мин беләм.* Н. Арсланов. || Нәфис әдәби тел чараларына карата. *Бу әсәр шагыйрьнең палитрасы яңа буяулар, төсмерләр, бизәкләр белән баюы турында сөйли.* Н. Юзиев.

ПАЛЛА'ДИЙ *и.* Үзенең водородны бик күп микъдарда йоту сәләте белән аерылып торган химик элемент — көмеш сыман ак металл.

ПАЛЛАМА *диал.* Телдән әйтелгән, белдерелгән фараз, гипотеза. *Палламасы туры. Палламасы дөрескә чыкмау.*

ПАЛЛИАТИВ *и.* 1. Авырудан терелтми, ләкин авыртуны басып, хаста кешегә бераз җиңеллек бирә торган дару-дәрман.

2. *күч.* Мәсьәләнең, кыенлыкның өлешчә яки вакытлыча гына хәл ителүенә китерә торган чара.

ПА'ЛУБА *и.* 1. Судно өстенә яки суднодагы терәкләргә беркетелеп җәелгән идән. *Югарыгы палуба. Аскы палуба.* □ *Палубадан кешеләрне куа, Мачталарны шыгырдата җил.* Ф. Кәрим. *Палубадан карап барам, Су өсте — көзге, Тик артта бөтерелеп кала Пароход эзе.* Н. Арсланов.

2. Төзелеш басмасы. *Йорт салу өчен палуба кору.*

ПА'ЛЬМА *и.* Ботаксыз, шома һәм биек кәүсәсенең башында гына берничә каурый яки җилпәзә сыман гаять эре яфрагы булган мәңге яшел көньяк агачы, хөрмә талы. *Пальмалар аллеясы. Пальма яфрагы.* □ *Пальмалардан төшә күлләгә, Җир җәннәте якынтирәдә. Җир җәннәте торсын бер читтә, Бодай басуына ни җитә.* Г. Афзал.

ПАЛЬПА'ЦИЯ *и. мед.* Тәндәге авырткан урынны яки гомумән авыруны бармак белән капшап тикшерү методы.

ПАЛЬТО *и.* Чабуы тездән югары булмаган һәм гадәттә салкында киелә торган өске кием. *Кышкы пальто. Көзге пальто.* □ *Вафа кызыл күлмәк өстеннән каеш буган. Өстендә искерәк, хәтфә якалы мехсыз пальто.* М. Фәйзи. *Искәндәрев --- бер дә ашыкмыйча пальтосының төймәләрен ычкындыра.* Ә. Еники.

ПАЛЬТОЛЫК *с.* Пальто тектерергә ярый яки җитә торган. *— Син миңа пальтолык коверкот алып бирсәң, мең өлеш артык булыр.* К. Тинчурин. | *и. мәгъ. Пальтолык алу.* || Пальто булдыру өчен билгеләнгән. *Пальтолык акча.*

ПАМФЛЕТ *и.* Берәр күренешкә яки берәр шәхескә каршы юнәлдерелеп язылган үткен сатирик әсәр — мәкалә, брошюра һ. б. *„Яңа Кисекбаш" либреттосы --- сатирик әйбер булсын. Дию әкияте, Карәхмәт сугышлары иске тормышка памфлет төсендәге көлке хыял, әкият булсыннар.* М. Җәлил. *Нури хәлфә мәктәбе турында --- шундый памфлет та чыгып өлгерде. Бу памфлетның авторы Габдулла иде.* Ә. Фәйзи.

ПАМФЛЕТЧЫ *и.* Памфлетлар язучы әдип-сатирик.

ПАН *и.* 1. Иске Польшада һәм иске Литвада: алпавыт, барин. *Сез паннарга кием кидердегез, Сез паннарның җирен сөрдегез, Сез паннарга җимеш үстердегез, Үзегез ач-ялангач йөрдегез.* Ә. Ерикәй. *Әй, кистек без Деникинны, Поляк паннарын!* Ф. Кәрим.

2. Польшада һәм Чехословакиядә өлкән ир кешегә хөрмәтләп эндәшү сүзе. *Җир сөрүче поляк --- атын буразнага борды. — Хәерле көн, пан! — диде Гаяз. — Әйтегез әле, пан, Воңцево биредән еракмы?* А. Расих.

ПАН- Кушма сүзләрдә „бөтен, барлык" дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: **панамерика уеннары, пангерманизм, панславизм.**

ПАНА'МА *и.* Киң кырпулы җәйге эшләпә. *Сөләйман --- җәйлек ак киемнән, панамадан.* Ф. Әмирхан. || Нарасый һәм сабый балаларга кидерелә торган тукыма эшләпә. *Бәбигә панама тегү.*

ПАНАРИ'ЦИЙ *и. мед.* Бармакка, кулга чыга торган эренле шеш. *Дминә панарициенең җан өзгеч газаплы шеш булуын белсә дә, --- моның ише азып киткән рәвешен күргәне юк иде әле.* Г. Минский.

ПАНБӘРХЕТ *и.* Юка, нәфис бәрхет. *Илһам Гөлиянең туган көнендә бүләк итеп панбәрхет күлмәклек бирде.* И. Салахов.

ПАНДЕ'МИЯ *и.* Берәр зур илгә яки бөтен бер географик өлкәгә, континентка таралган эпидемия. *Грипп пандемиясе.*

ПАНДУР *и.* Грузиннарның кул белән чиртеп уйный торган кыллы музыка коралы. *Пандурда уйнау.* □ *Пандур теле булса сиңа чит-ят, Аңа орынма син.* Н. Арсланов.

ПАНЕГИ'РИК I *и. кит.* Кемне дә булса мактап сөйләнгән нотык. *Панегирик уку.* || *күч.* Гомумән күп сүзле мактау.

ПАНЕГИ'РИК II *с.* Мактауга багышланган (әдәби әсәр, нотык турында). *Г. Тукай солтанны күкләргә чөя торган панегирик төрек поэзиясенең сәнгатьчә мәгънәсезлегеннән, иҗтимагый һәм әхлакый бушлыгыннан көлде.* Г. Халит.

ПАНЕЛЬ *и.* 1. *к.* тротуар. *Безнең шәһәрләребезне эре мозаика түшәлгән мәйданнар, төсле панельләр бизәп торачак.* Эврика.

2. Бинадагы эчке стеналарның бер тәңгәлдә тигезләп буялган яки такта һ. б. белән тышланган аскы өлеше. *Акшарлы түшәм, аңа асылган электр лампалары, зәңгәр панельләр — һәммәсе берьюлы авыш-түеш килгәндәй булды.* Б. Камалов.

3. Стенаны һ. б. бизәү яки приборларның күрсәткечләрен һ. б. урнаштыру өчен махсус каймаланган өслек. *Балконнан --- электрон-исәпләү машинасының контроль панеле --- күренә.* Каз. утл.

4. Шахта, карьер кебек урыннарда махсус аерып билгеләнгән турыпочмаклы яки квадрат участок. *Яңа панельгә күчү.*

5. Җыелма конструкцияләрдән салына торган бина яки корылманың гадәттә яссы формада булган бер кисәге. *Төзелеш мәйданына китерелгән блоклар, панельләр, тимер-бетон конструкцияләр --- кран ярдә-*

мендә туп-туры өскә, тиешле урынга бирелә. М. Хәсәнов.

Панель ташыгыч — төзелеш панельләрен ташырга махсус җайланмасы булган автомашина. *Илебез бу төзелешкә өч мең автомобиль, биш йөз экскаватор, меңләгән бульдозер, панель ташыгыч, скрепер җибәрде.* Каз. утл.

ПА'НИКА *и.* Бик күп кешеләрнең берьюлы куркуга төшеп, көрәшү, каршылык күрсәтү ихтыярын югалту күренеше. *Паника куптару. Паника салу. Паникага бирелү.* □ *Солдатлар арасында шау-шу китте, паника башланды.* М. Гали. *Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә, дип.* Ә. Еники. || Куркып, шүрләп аек акылны югалту, бик каты курку күренеше. *Каюмның гаҗәпләнүенә каршы, Нәсимә паникага төшмәде.* Ш. Камал.

ПА'НИКАСЫЗ *рәв.* Паникага бирелмичә, тыныч һәм тотнаклы рәвештә. *Паникасыз, аек, тыныч, ләкин җитди төстә барысы турында да уйла.* М. Җәлил.

ПАНИКЁР *и.* Паникага бирелүче; паника таратучы.

ПАНИСЛАМИЗМ *и.* Ислам динендәге халыкларны ислам дине флагы астында бер дәүләткә берләштерү идеясе белән сугарылган реакцион политик агым.

ПАНИСЛАМИСТ *и.* Панисламизм тарафдары, панисламизм хәрәкәтендә катнашучы. *Беренче революциядә дә татар әчендә үзләренә күрә бер агым булып килгән пантюркистлар, панисламистлар бар.* Г. Ибраһимов.

ПАННО *и.* 1. Стенаның яки түшәмнең махсус орнамент белән уратылып алынган һәм нинди дә булса рәсем, бизәк һ. б. төшерелгән бер өлеше.

2. Шул аерым өлеш өслегендәге рәсем, бизәк яки барельеф.

ПАНО'ПТИКУМ *и. иск.* Балавыз сыннар һәм сирәк очрый торган төрле әйберләр музее.

ПАНОРАМ: панорам кинотеатр — панорам фильмнар күрсәтү өчен җайланган кинотеатр.

Панорам фильм — ярымтүгәрәк яки түгәрәк залда, махсус экранда күрсәтелә торган фильм.

ПАНОРА'МА *и.* 1. Биек яки ачык урыннан күренеп торган киң манзара, киң күренеш. *Көймә Устьедан ераклашкан саен, төнге шәһәр панорамасы киңрәк җәелә.* К. Нәҗми. *Тәрәзә яныннан гына исәпсез-хисапсыз йорт түбәләре, моржалар, антенналар панорамасы җәелеп китә.* Г. Әпсәләмов.

2. Түгәрәк бүлмәнең тоташ стенасына төшерелгән зур картина. *Ләкин бу нәрсә [әлфия ясаган картина] бит чын сәнгать әсәрләре дәрәҗәсенә менеп җитмәгән бер панорама гына.* Г. Бәширов.

3. *махс.* Артиллерия коралларын төзәү өчен кулланыла торган оптик прибор.

ПАНСИОН *и.* 1. Иске Россиядә һәм чит илләрдә: үз тулай торагы яки интернаты булган урта мәктәп; шундый мәктәпнең интернаты. *Тангатаров --- гимназиянең пансионында сәяси түгәрәктә доклад ясап торганда [полиция кешеләре] килеп басканнар.* Г. Ибраһимов. *Мин атаклы педагог Сюар әфәнде пансионына йөрим һәм тулай тораста урын җитмәгәнгә күрә генә квартирда торам.* А. Тимергалин.

2. Чит илләрдә, иске Россиядә: үзендә яшәүчеләрне азык-төлек белән тулысынча тәэмин итеп торган гостиница.

ПАНСИОНАТ *и. к.* пансион (2 мәгъ.). *Муса [Җәлил] Оренбургка килгәч „Хөсәения" мәдрәсәсенә керә, --- шунда, пансионатта торып, укуын дәвам иттерә.* М. Гайнуллин.

ПАНСИОНЕР *и.* Пансионда торучы кеше (укучы, мөсафир һ. б.).

ПАНТ *и.* Чуар болан, марал һәм изюбрларның дару препаратлары ясауда файдаланыла торган, әле сөяклəнеп җитмәген яшь мөгезе.

ПАНТАЛОН *и.* 1. Бот һәм аякны кысып тора торган бик тар чалбар — иске Россиядә, бигрәк тә XIX гасырда, модада булган. *Панталон тектерү.* □ *Инспектор кызу адымнар белән өстәлгә таба юнәлде. Өстендә кара фрак, ак жилет һәм зәңгәр панталон.* Җ. Тәрҗеманов.

2. Гәүдәнең билдән түбәнге өлешен каплап тора торган хатын-кыз эчке киеме.

ПАНТЕИЗМ *и.* Табигатьне алла яки алланың гәүдәләнеше дип карый торган дини-фәлсәфи тәгълимат.

ПАНТЕИСТ *и.* Пантеизм тарафдары.

ПАНТЕИ'СТИК *с.* Пантеизмга мөнәсәбәтле; пантеистларга охшаш. *Пантеистик карашлар.*

ПАНТЕОН *и.* 1. Борынгы грекларда һәм римлыларда аллаларга багышланган храм.

2. *җыйм.* Нинди дә булса берәр диндә булган барлык аллалар. *Һинд аллалары пантеоны.*

3. Берәр илнең, өлкәнең атаклы кешеләре күмелгән махсус урын — мавзолей, тәкия, төрбә. *Төрбәләр бар, пантеоннар, Гротлар бар җирдә.* Р. Әхмәтҗанов.

ПАНТОКРИН *и. мед.* Пантлардан алына торган дару препараты (организмны тынычландыру һәм шул ук вакытта көчәйтү сәләтенә ия).

ПАНТО'МЕТР *и.* Якынча төгәллек белән топографик план төшерүдә кулланыла торган почмак үлчәгеч инструмент.

ПАНТОМИ'МА *и.* Персонажларның хисләре һәм фикерләре йөз һәм тән хәрәкәтләре аркылы белдерелә торган театраль тамаша. [*Аулак өендә*] *тамаша баштанаяк бары тик уен, җыр-бию һәм пантомимага корылган.* Н. Исәнбәт. *Пантомима тамашачының өзлексез көлүе астында дәвам итә.* И. Рәмиев.

ПАНТОПОН *и. мед.* Составында морфий булган дару препараты.

ПАНТЮРКИЗМ *и.* Татар, башкорт, казах, үзбәк һ. б. төрки халыкларны Төркия кул астында берләштерүне максат итеп куйган реакцион иҗтимагый агым. [*Татар буржуазиясе*] *шул изелгән милләт маскасы астында контрреволюцион панисламизм, пантюркизм хәрәкәтен бөтенләе белән үз кулына алырга җыена.* Т. Гыйззәт.

ПАНТЮРКИСТ *и.* Пантюркизм тарафдары. *Пантюркистлар хәрәкәте.* | *с. мәгъ. Тукай --- пантюркист журналистларны реакциянең үзәгендә торучылар дип аңлады.* Г. Халит.

ПАНТЮРКИ'СТИК *с.* Пантюркизмга мөнәсәбәтле, пантюркизм идеясенә ярашлы. *Буржуазия --- халыкны алдау өчен „дин", „милләт" әламен кутәреп, Идел-Урал штаты дигән пантюркистик аванпюрасын корды.* М. Җәлил. *Г. Ибраһимов татар милләтчелегенең тел һәм әдәбият өлкәсендәге пантюркистик ниятләренә каршы чыккан иде.* Г. Халит.

ПАНТЮРКИСТЛЫК *и.* Пантюркист булу. *Пантюркистлык гадәттә Төркия дәүләте йөрткән агрессив политикага мөнәсәбәттә бик ачык чагыла.* Каз. утл. *Бу хикәядә алынган сурәт — пантюркистлык белән саташып йөргән милләтче Харисов.* Г. Нигъмәти.

ПА'НЦИРЬ *и.* 1. *тар.* Бик күп вак металл бөжраларны бер-берсенә кертеп ясалган хәрби күлмәк, көбә.

2. Кайбер хайваннарның тиресе урынына яки тире өстенә үскән сөяк кабык. *Панцирьлы балыклар гәүдәсенең баш һәм алгы өлешен каты сөяк панцирь каплап алган, бу каты кабык аларның тәнен саклау өчен хезмәт иткән.* Үтк. зам. сәяхәт.

3. Хәрби корабларның, поездларның махсус металл тышлыгы.

ПА'НЦИРЬЛЫЛАР *и. күпл. зоол.* Үлеп ибеткән борынгы хайваннар классы. *Силур диңгезләрендә балыксыман панцирьлылар яшәгән.* Үтк. зам. сәяхәт.

ПА'ПА *и.* Католик чиркәвенең иң зур рухани башлыгы. *Католик руханиятенең --- хөкүмәте папаның пайтәхете булган Рома [Рим] шәһәрендә.* Ф. Әмирхан.

ПАПА'ХА *и.* Йонлач ягы тышка каратып тегелгән цилиндр формасындагы колаксыз, тирән мех бүрек. *Каракүл папаха.* □ *Бүгенгедәй хәтеремдә: Ибрай солдат, папахасын салып, башын түбән иде.* М. Сөндекле.

ПАПА'ХАЛЫ *с.* Папаха кигән. *Ротаның алдыннан баручы биек сорғылт папахалы, таза гәүдәле командир турысына килеп җитүгә, Митричев атларны туктатты.* Г. Бәширов.

ПАПИРОС *и.* Эченә тәмәке тутырылган һәм авызга кабу өчен буш өлеше булган кәгазь көпшә. *Газизов эченә йоткан төтенен --- өреп чыгарды да, папирос башындагы көлне кага-кага, сөйләвендә дәвам итте.* А. Шамов.

Папирос кәгазе — бик юка кәгазь сорты.

ПАПИ'РУС *и.* 1. Күрәнчәләр семьялыгыннан тропик илләрдә үсә торган камышлы үсемлек. *Укытучы Барый абый Янчурин папирус дип аталган тропик үсемлекнең яфракларына борынгы халыкларның язып калдыруларын сөйләде.* Г. Ахунов.

2. Шул үсемлекнең сабагыннан телеп эшләнгән борынгы язу материалы. *Кәгазь килеп чыкканга чаклы папируска яза торган булганнар. Аны Нил ярларында үсә торган биек күрән сабакларыннан ясаганнар.* Робинзон эзл.

3. Шундый язу материалына язылган борынгы ядкарь, кулъязма. *Безнең эрага кадәр 2000 ел чамасы элек язылган Мисыр папирусында билгесез санны табуга мәсьәләләр бар.* Алгебра.

ПА'ПКА *и.* Эченә кәгазьләр, дәфтәрләр салып кую өчен ясалган катыргы яки күн тышча. *Папкадагы документлар.* □ *Муса кулъязмаларын папкаларга салып бәйләде.* Ш. Маннур. || Тоткасыз портфель. *Култыкка папка кыстыру.* □ *Райком секретаре өстәлдән бер кәгазь алып папкасына салды.* Г. Гобәй.

ПАПУАС *и.* Яңа Гвинея утравының һәм шуның янындагы башка ваграк утрауларның җирле халкы, шул халыкның аерым бер кешесе. *Папуас телләре. Папуас кабиләләре.*

ПАПЬЕ-МАШЕ *и.* Кәгазь вагына җилем, гипс, крахмал кушып ясалган масса (такта яки катыргы ясауга китә).

ПАР I *и.* 1. Сыекча кисәкчекләренең күпләп очып күтәрелүеннән барлыкка килгән газ. *Су пары. Бензин пары.* □ *Менә казан кырыеннан пар бәрә башлый. Кайсыдыр йөгереп барып казан капкачын ача.* И. Гази. *Авыл көтте җирләр ачылганны, Җылы парлар җирдән чыкканны.* Ш. Маннур. || Берәр бүлмәне, торакны җылыту яки берәр машинаны хәрәкәткә китерү өчен махсус ясалган, пар белән һавадан торган эссе катнашма. *Пар басымын арттыру.* □ *Искән җилнең эсселеге, мунча ташыннан чыккан пар шикелле, битне пешерә иде.* Ш. Мөхәммәдев. || *с. мәгъ.* Парны булдыра яки туплый торган. *Пар казаны.* || *с. мәгъ.* Пар көче белән эшли торган. *Пар машинасы. Пар турбинасы.* □ *Актүбә шәһәренең ак өйләре, пар тегермәне морҗалары күренде.* Ш. Усманов.

2. Үсемлекләр бүлеп чыгара торган газ хәлендәге органик матдәләр (эфирлар һ. б.). *Үсемлекләрнең исле пары борынны кытыклый һәм үпкәләргә сыланган кебек була.* Ә. Еники.

3. *күч.* Кызулык, дәрт, темперамент. *Бөтен парың биреп омтыл алга, Уртәләмә йөрәк ярасын.* Ф. Кәрим. *Фазылҗанов, сугышчан әтәч кыяфәтеннән чыгып, үз кыяфәтенә кергән, пары яхшы ук басылган.* Ф. Хөсни.

4. *күч.* Исерткеч эчемлек тәэсире. *Бу мидә [Кисекбаш миендә] мең пот сыраның пары бар.* Г. Тукай.

Пар көче — пар казанындагы пар басымының көче. *Лектор сүзне --- Фултонның пар көче белән йөрүче көпчәкле пароходына китереп җиткерде.* М. Хәсәнов. **Пар күтәрү (төшерү)** — пар машинасында пар басымын арттыру (киметү). *Әй, машинист, каула атыңны; әй, кочегар, күтәр парыңны.* Ә. Исхак. **Пар салу (өстәү)** — 1) пар чыгышын арттыру өчен мунча ташына су сибү. *Карчык, аңа суык тигән дип уйлап, мунча якты, күп итеп пар салып, каен себеркесе белән Рәүфәне бик каты чабындырды.* А. Шамов; 2) *күч.* кыйнап-сугып яки шелтә биреп, кызурак, яхшырак эшләргә мәҗбүр итү, кыздыру. *[Арбада баручы] атына шәп кенә пар өстәмәкче булып селтәнде.* Ф. Хөсни.

ПАР II *и.* 1. Сөрелеп тә, җир ял итсен өчен чәчелми калдырылган җир, такыр басу. *Пар басуларында елына ике тапкыр уңыш алына, чөнки чиста пар басулары биләмле парларга алыштырылды.* Г. Галиев.

2. *сөйл.* Парга сөрү эше.— *Игеннәрегез бик әйбәт күренә. Инде синең парың да күп калмаганга охшый. — Пар иртәгә бетә. Тарыны --- утадык.* Г. Бәширов. *Яңгыр чакыра басуларга, язгы парга.* М. Җәлил.

Пар күтәрү (сөрү), парга сөрү — парга калдырылачак җирне сөрү. *[„Сабанчы“ колхозчылары] иртә парларын сөрергә, печәнгә чыгарга эшче көчләре сорап миңа килгәннәр иде.* Т. Гыйззәт.

ПАР III *с.* 1. Бер бөтен (комплект) тәшкил итә һәм бергә кулланыла торган, беришле ике (предмет). *Бер пар итек. Бер пар чаңгы.* □ *— Ике пар бияләй, бер пар оекбаш, бәти йоныннан гына.* Г. Бәширов. || Бергә йөри торган, бергә кулланылган ике (нәрсә, зат). *Көнтәләп пар чилләген, Суга бара чибәрем.* Ф. Бурнаш. *Өч пар ишкәкне алты кеше бер уңай белән күтәреп сала башлагач, ул [көймә], дулкыннар белән көрәшә-көрәшә, эчкә таба үрмәләп кимте.* Ш. Камал. || Комплект, бер-берсен тутырып тора һәм икесе бергә кулланыла торган ике (предмет). *Хәзер Зәйнәпбануларның сыеры да бар, кәҗәләре дә, пар „кәчтүн“-чалбар да, тик кияү үзе генә юк иде.* Г. Бәширов.

2. Ике данә, ике, икәү. *Олы юлкайлардан узганда ла Пар каеннан кистем лә пар кашык. Пар каеннар көбек, әй, шаулашып, Яшь гомерләр үтсен парлашып.* Җыр. || Бергә торган ике беришле (нәрсә). *Иркәм белән икебез, Пар алмадай битебез.* М. Җәлил.

3. *и. мәгъ.* Ир белән хатын яки егет белән кыз. *Гашыйк парлар.* □ *Музыка яңгырый, биюче парлар бер-берсе артыннан хыялый дулкыннар шикелле агылалар.* Ф. Әмирхан. *Кояш баеган вакытта --- ун пар, --- атларын узыштырып, --- Шырданга кайтып керделәр.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Яңенси теләк чорында яки даими рәвештә гаилә тәшкил итеп торучы (иркәк белән теше). *Пар карлыгач. Пар үрдәк.* □ *Пар юрга гына шулай уйнашыр, Пар сандугач кына шулай сайрашыр.* Ф. Бурнаш. || *и. мәгъ.* Гашыйкларның берсе. *— Парын югалткан сыңар күгәрчендәй, мин генә моңаеп утырдым.* Г. Бәширов.

4. Тиң; лаеклы, кулай. *Матур егет пар кыз таба, Йөрми гомер уздырып.* Г. Камал. || Тигез, бердәй, тиң. *Эштә көчем шул егетләр белән пар минем.* Ф. Кәрим.

5. *к.* пардан.— *Әгәр шул кызны миңа димләп, чыгарып бирә аласың икән, --- шахтадан беренче кайтканда ук сиңа әни белән пар күлмәк.* А. Шамов.

6. *рәв. мәгъ.* Бергә, бергәләп, тиң. *Митрий Иваныч белән пар эшләгәндә кызу тотмыйча кара.* Г. Әпсәләмов.

Пар ат — бер чанага яки арбага җигелгән ике ат. *Гади арбага пар ат җиккән бер кеше шәп итеп*

артымнан килеп тә җитте. М. Гафури. **Пар тояклылар** — имезүчеләр классыннан сыер, кәҗә, поши кебек һәр аягында икешәр аеры тоягы булган хайваннарны эченә алган бер отряд.

◇ **Пар килү** — бер-берсенә тиң булу, тиң булып күренү. *Икегез дә пар килгәнсез — Гөрләп гомер итегез.* Җыр. **Пар күгәрчен кебек** — бер-берсен бик сөешеп, бик яратышып. *Пар күгәрчен кебек гөрләшеп, Ике йөрәк бергә берләшеп, Ике ялкын бергә кушылган.* Ш. Маннур. **Парга килү** — бер-берсенә туры килеп, бер бөтендәй булып тору. [*Карлыгачның тавышы*] *иптәш кызының тавышы белән шундый парга килә.* Г. Бәширов.

ПАРАБЕ'ЛЛУМ *и.* Автомат принцибында ата торган пистолетларның бер төре. *Өстәл өстендә ялтырап яткан парабеллум һәм --- пистолетны алып Беркутовка бирдем.* Ә. Айдар. *Шпигель әфәнде --- хәтта кобурындагы парабеллумын суырып чыгармакчы була иде.* Ш. Маннур.

ПАРА'БОЛА *и. мат.* Ике очы үзара кисешми һәм тоташмый торган симметрик кәкре сызык. *Парабола күчәре.*

ПАРАБОЛИК *с.* Парабола формасындагы. *Параболик антенна.* || Параболаның сынар очы (ябе) формасындагы. *Параболик траектория.*

Параболик тизлек — икенче космик тизлек (секундка 11,2 *км*).

ПАРА'ГРАФ *и.* 1. Текстның бүлек яки бүлекчәсе эчендә үзенә аерым әһәмияте булган өземтә, өлеш. *Моннан соңгы параграфларда без практикада бик еш кулланыла торган кайбер формулаларны карап чыгарбыз.* Геометрия.

2. Шундый бүленешнең баш тамгасы (§ билгесе).

ПАРАД *и.* Кул астында булган хәрби көчләрнең тантаналы рәвештә каралуы. *Хәрби парад.* □ *Бәйрәм көнне парад булды. Полк командиры бөтен роталарны „церемониальный марш" белән үткәрде.* А. Таһиров. || *күч.* Спортчылар, пионерлар, яшьләр һ. б. ш. ның бердәм, тантаналы йөреше. *Д иртәсен инде урам тулып Үткәрдек без бәйрәм парады.* Ш. Маннур.

ПАРАДИ'ГМА *и. лингв.* Сүзнең төрләнеш үрнәге итеп бирелгән формалар таблицасы.

ПАРА'ДНЫЙ *и. сөйл.* Йортның, бинаның урам ягына яки киң йорт алдына чыга торган иң зур ишеге. *Дгәр --- парадныйдан чыксам, ихтимал, бикәгә очрармын, дип куркып, Батыргали агай --- арттагы ишектән чыкмак булып кухняга керде.* Ш. Мөхәммәдев. *Үтеп барам шулай урам буйлап, Парадныйда күрәм бер бала, Звонокка үрелә, буе җитми.* М. Җәлил.

ПАРАДОКС *и.* Гомум кабул ителгән һәм дөрес дип саналган фикерләргә, күзаллауларга кискен рәвештә каршы булган, (кайвакыт беренче карашта) кеше ышанмаслык булып тоела торган фикер, хөкем яки күренеш. *Зенон* [*борынгы грек галиме*] *парадокслары.* □ *Тормыш парадоксларны кирәгенчә сәхнәгә ыргытып тора: бик яхшы укыган, яңы-төне белән гыйлемгә бирелгән бала институтка керә алмаска мөмкин.* М. Мәһдиев.

ПАРАДОКСАЛЬ *с.* Парадокс булып күренә торган. *Парадоксаль фикерләр. Парадоксаль хәл. Парадоксаль ситуация.*

ПАРАЗИТ *и.* 1. Башка бер тере организм хисабына, аның тән өстендә яки эчендә канын эчеп яки сүлләрен суырып яшәүче икенче бер тере организм. *Хайван һәм үсемлек паразитлары.* | *с. мәгъ. Паразит бөҗәкләр. Паразит гөмбәләр.*

2. *күч.* Җинаятьчел рәвештә хезмәт ияләре көченнән файдаланып яши торган кеше.— *Д паразитларның кем җилкәсендә яшәүләрен сез бик яхшы беләсез.* К. Тинчурин. *Г. Камал халык дошманнарыннан, төрле паразитлардан, контрреволюцион байлардан ачы рәвештә көлә.* Г. Кашшаф. || *гади с.* Сүгү яки сүгенү сүзе.— *Менә бу паразит сезнең намусыгызга тап төшерә торган сүзләр сөйли.* Т. Гыйззәт. *Зиннәт аның* [*әпипә танышының*] *артыннан карап тордыторды да: Паразит! — диде, төкереп куйды.* Г. Бәширов.

ПАРАЗИТИЗМ *и.* Паразит булу хасияте; паразитларча яшәү күренеше, паразитлык. *Монополияләр хакимлеге --- капитализмны паразитизмга, черүгә китерде.* Иң яңа тарих.

ПАРАЗИТЛА'РЧА *рәв.* Паразитларга хас булганча; паразитларга охшап.

ПАРАЗИТЛЫК *и.* Паразит булу күренеше, сыйфаты; паразитизм. *Ничек атарга мондый чирне — хезмәтне сөймәү, хезмәттән качу чирен? Паразитлык!* Г. Минский.

ПАРАЛИ'ТИК I *с.* Паралич суга торган, параличлый торган. *Паралитик авыру.*

ПАРАЛИ'ТИК II *и.* Паралич суккан, параличланган кеше. [*Шәмгун:*] *Бөтен җаны, дәрте, теләге, ихтыяры суырылып алынган паралитик хәлендә мин хәзер.* Ә. Фәйзи.

ПАРАЛИЧ *и.* Тәннең нинди дә булса бер әгъзасын үз функциясен үтәүдән, хәрәкәтләнүдән туктата торган авыру. *Йөрәк параличыннан үлү.* □ *Менә алты ай булды, углым ишетми вә сөйләшә алмый, башын паралич суккан.* Ф. Әмирхан.

ПАРАЛИЧЛАНУ *ф.* 1. Паралич хәленә килү, төп функцияләрен үтәүдән туктау (тән әгъзаларының һ. б. турында). *Юк, Вуд уяна алмый — аның аңы параличланган иде.* А. Тимергалин.

2. *күч.* Үз функциясен үтәүдән туктау (иҗтимагый оешмалар һ. б. турында). *Башкалада анархия. Хөкүмәт параличланган.* К. Нәҗми.

ПАРАЛИЧЛАУ *ф.* Паралич хәленә китерү.

ПАРАЛЛЕЛЕПИ'ПЕД *и.* Нигезләре булып параллелограммнар хезмәт итә торган геометрик җисем. *Йортлар, бүлмәләр, шкафлар, йортлар төзү өчен тимер-бетон плиталар, кирпеч һ. б. турында параллелепипед формасында булалар.* Геометрия.

ПАРАЛЛЕЛИ'ЗМ *и.* 1. *мат.* Параллель булу күренеше, параллельлек.

2. Тормыш яки табигать күренешләрендә, шулай ук сәнгать һәм әдәбияттә кулланылган детальләр параллель булып килү. *Параллелизм — бер күренешне икенче бер күренеш яктысында тасвир итү. Дәтик, чәчәкләр һәм балалар* [*еш кына*] *параллель рәвештә тасвир ителәләр.* Г. Кутуй. *Бу әдип* [*Г. Ибраһимов*] *табигать күренешләре белән кешеләр психологиясе арасында параллелизмнар да ясаштыргалый.* Г. Нигъмәти. || Кабатлану, бер-бер артлы килү яки бер үк вакытта янәшә яшәештә булу күренеше. *Фәнни-тикшерену темаларының параллелизмы.* □ *Спектакльдә указның, факелның һәм курайның кулдан кулга йөрүе кебек параллелизм — бер үк алымны кабатлаулар --- уңышсыз.* М. Җәлил.

3. *әд.* Тасвирлылыкны яки эмоциональлекне көчәйтү чарасы буларак, бер үк синтаксик конструкция кабатлану, мәсәлән: *Айның да бар йолдызы, Суның да бар кондызы.* Җыр.

ПАРАЛЛЕЛОГРАММ *и.* Капма-каршы яклары үзара тигез һәм параллель булган дүртпочмак. *Параллелограммның диагонале аны үзара тигез булган ике өчпочмакка бүлә.* Геометрия.

ПАРАЛЛЕЛЬ *с.* 1. *мат.* Бөтен озынлыгы дәвамында бирелгән бер сызыктан (яссылыктан) тигез ара

саклап сузыла һәм чиксез дәвам иткәндә дә шул сызык (яссылык) белән кисешми торган (сызык яки яссылык турында). *Параллель туры. Параллель яссылык.* □ *Геометрия буенча мәгълүм ки, параллель сызыклар кисешмиләр.* Г. Нигъмәти. | *и. мәгъ. Бирелгән сызыкка параллель сызу (үткәрү).*

2. Бер-берсенә (үзара) параллель булган (ике яки күбрәк сызыклар, яссылыклар турында). *Параллель урамнарны урап йөри-йөри, алар* [*Хәбир белән Мәдинә*] *Нариманга килеп җиттеләр.* Ш. Хөсәенов.

3. *и. мәгъ. геогр.* Җир шары өстендә экваторга параллель рәвештә һәм бер-берсеннән тигез ераклыкта уйланма рәвештә үткәрелгән сызыклар; киңлек (2 мәгъ.) үлчәме. *Көньяк параллельләр. Төньяк параллельләр.*

4. *и. мәгъ. күч.* Тормышта, табигатьтә, шулай ук сәнгать һәм әдәбиятта бер-берсе белән янәшәлек, бергәлек һәм берәр яктан беришле үзгәрүчәнлек күренеше. [*Ш. Камал*] *Габбасның семьядагы һәм эш, хезмәт шартларындагы тормышын матур параллельләрдә --- оста күрсәтә.* Г. Нигъмәти.

5. Бер системада, бер-берсен кабатлап, янәшә. *Параллель класслар булгач, план төзүгә, дәрескә хәзерләнүгә әллә ни вакыт китмәс.* А. Тимергалин. | *рәв. мәгъ. Төп темага параллель рәвештә әсәрдә Булат белән Рәйханәнең мәхәббәте бирелгән.* М. Җәлил.

6. Бер үк вакытта(гы) һәм бер төрле. *„Райурман" „Идел-урман" ширкәте белән параллель эш алып барган.* Ә. Фәйзи. | *рәв. мәгъ. Параллель эшләүче двигательләр.*

Параллель тоташтыру — электр чылбырындагы ике ноктаны ике яки берничә үткәргеч белән берьюлы тоташтыру. *Рушад --- яшь хатынга, параллель тоташтыруның схемасын сызып, шпаргалка бирде.* М. Мәһдиев. **Параллель үткәрү** — ике күренеш арасында,ягъни бирелгән күренешкә икенче бер күренештә охшашлык, аналогия күрсәтү; мисал китерү, мисалын табу.— *Ничек инде? — диде Хәбир, музыка белән медицина арасында параллель үткәрүгә төшенеп җитмичә.* Ш. Хөсәенов.

ПАРАЛЛЕЛЬЛЕК *и.* Параллель булу. *Сызыкларның параллельлеге.* □ *Лобачевский параллельлек төшенчәсен киңәйтә һәм баета. --- Кисешмәүче сызыкларның ул фәкать икесен генә параллельләр дип атый.* Ж. Тәрҗеманов.

ПАРАМАГНИТ *и.* Магнит яки ток кырында зәгыйфь кенә магнитлану галәмәте күрсәтә торган тирәлекләр (җисемнәр һ. б.).

ПАРА'МЕТР *и. мат.* **1.** Математик формулага бирелгән мәсьәлә шартлары буенча гына кертелә торган сан. *Спутникның хәрәкәтен һәм орбитасының параметрларын белгәннән соң, штурман кайсы төштә булуын төгәл исәплэп чыгара ала.* Эврика.

2. *физ.* Һәртөрле характерлы үлчәм.

ПАРАТИФ *и.* Тиф авыруының корсак тифына охшаган бер төре. *Паратиф белән авыру.*

ПАРАФИН *и.* Аксыл яки саргылт төстәге балавыз сыман синтетик органик матдә (нефтьтән, торфтан яки соры күмердән алына). *Нефть чыгу юлына парафин бик тыгыла, аны гел арчып торырга кирәк.* Р. Төхфәтуллин.

ПАРАФИНЛАУ *ф.* (Изоляцияләү сыйфатын көчәйтү өчен) парафин белән каплату яки парафин сендерү.

ПАРАФИНЛЫ *с.* Парафин сенделгән.

ПАРА'ША *и. гади с.* Төрмә камераларында, карцерларда тәрәт итү һәм пычрак сулар салу өчен зур чиләк. *Баязит ишек төбендә тынчып, сасып утырган пычрак парашаны җирәнә-җирәнә ике кулы белән күтәреп ала да коридорга чыга.* Г. Ибраһимов.

ПАРАШЮТ *и.* Очкыч аппаратлардан җир өстенә сикереп төшү яки әйберләр төшерү өчен бик зур зонд рәвешендәге җайланма. *Бу кеше моннан берничә минут элек очкычтан парашют белән сикергән Хәсән иде.* А. Расих. *Самолет китеп барды һәм шунда ук һавада парашют ачылып китте.* Г. Гобәй.

ПАРАШЮТЧЫ *и.* Очкычтан парашют белән сикерүче яки сикергә өйрәнгән кеше. *Парашютчылар десанты.* □ *Таня институтта парашютчылар түгәрәге оештырды: врач өчен парашюттан сикерә белү иң кирәкле нәрсә.* Г. Әпсәләмов.

ПАРАШЮТЧЫЛЫК *и.* Парашют белән сикерүнең теория һәм практикасы; парашют спорты. *Парашютчылык белән шөгыльләнү.*

ПАРДАН *рәв.* Икесенә, икәвенә бер үк төрледән. *Пардан киену.* □ *— Менә, Гөлшат белән икегезгә пардан сәгатьләр алдым.* Т. Гыйззәт.

ПАРДАШ *и.* **1.** Ике кешелек эштә, шөгыльдә кем белән дә булса бергә эшли торган кеше. *Пардашыңа лаек булу.* || Ике сменалы бер эштә алмашчы. *Пардашыңа ярдәм итү.*

2. Үзеңә тиң, үзеңә охшаш кеше, дус, иптәш. *Без күптән кан кардәшләр, --- Игезләр һәм пардашлар.* З. Нури.

ПАРИ *и. кит.* Бәхәс (ядәч) шарты. *— Мин пари тәкъдим иттем: кем шул кыя астындагы оясыннан каракошның баласын тотып алып чыга...* Ә. Фәйзи.

ПАРИК *и.* Башка кешедән кисеп алынган яки ясалма чәч — бизәнү-төзәнү яисә кыяфәтеңне үзгәртү чарасы буларак кулланыла. *Кайда синең дөрес кыяфәтең? Йөзең грим, чәчең парикта.* М. Җәлил. *Хәдичә рус карты дип уйлаган бу кеше Хөсәен үзе иде. Ул сакалмыек ябыштырган, парик кигән.* А. Расих.

ПАРИКМА'ХЕР *и.* Сакал-мыек кыру, чәч алу, чәч бөдрәләү, чәч буяу кебек эшләр белән шөгыльләнүче оста. *Сакал-мыеклар борын астыннан башларын сузарга өлгерә алмыйлар, мескеннәр, хәзер шул парикмахерга юнәләбез.* һ. Такташ.

ПАРИКМА'ХЕРЛЫК *и.* Парикмахер һөнәре; парикмахер булу. *Анна Андреевна парикмахерлык хезмәтендә егерме икенче елын эшли.* Ф. Хөсни.

ПАРИКМАХЕРХАНӘ *и. иск. к.* парикмахерский.

ПАРИКМА'ХЕРСКИЙ *и.* Парикмахерлар эшли торган махсус бина яки бүлмә. *— Ә Ленин нинди кече күңелле булган, --- җәяү йөргән, --- парикмахерскийда чират көтеп утырган.* Ә. Фәйзи.

ПАРК *и.* **1.** Аллеялары, чәчәкләкләре, ял итү өчен махсус корылмалары һ. б. булган зур бакча. *Культура-ял паркы.* □ *Сәгать җиденче булганга күрә, кояшның эссесе сүрелгән, музыка башланган, паркның кызыл ком сибелгән киң, озын юллары йөрүчеләр белән тулган иде.* Ф. Әмирхан. *Тирә-якта рәт-рәт тезелгән карт агачлар. Ләкин бу табигый урман түгел. Моны кеше утырткан, бу — парк.* Г. Әпсәләмов.

2. Транспорт чаралары (васиталары) эштән туктап тору һәм аларны ремонтлау өчен махсус урын, махсус корылмалар комплексы. *Трамвай паркы.* □ *Без колхозыбызның машиналар паркына барып чыктык.* Г. Галиев. || *җыйм.* Кул астында булган һәртөрле транспорт машиналары. *Колхозның трактор паркы.*

3. *хәрби.* Армия частьларын тәэмин итә торган күчмә склад. *Артиллерия паркы. Моторота паркы.*

ПАРКЕТ *и.* **1.** Идәнгә түшәү өчен кулланыла торган төрле геометрик формадагы шома такта кисәкләре. *Имәннән мичкәләр һәм паркетлар ясыйлар.* Робинзон әзл. *Идәндге паркет шакмакларын санап йөргәннән соң гына, кәгазь алып хикәянең планын яза башлауга, ишектән Хәлил кереп сәлам бирде.* К. Тин-

чурин. || *с. мәгъ. к.* паркетлы. *Паркет идәндә кояш нурлары уйный.* А. Әхмәт.

2. Шундый такталардан тезеп җәелгән идән. *Паркетта бию.*

ПАРКЕТЛЫ *с.* Паркет түшәлгән (идән турында). *Командир шома боздай ялтыраган паркетлы идәнгә саклык белән баса.* И. Туктар.

ПАРКЕТЧЫ *и.* **1.** Паркет шакмакларын ясаучы. *Казандагы [капиталист] Лок фабрикасының паркетчылары баш күтәрде.* А. Расих.

2. Идәнгә паркет җәюче. *Төзелештә паркетчы булып эшләү.*

ПАРЛАГЫЧ *и.* Нәрсәне дә булса пешекли, парлый торган җайланма (корылма). *Агач белән сәүдә итүче әре сәүдәгәрләрнең һәрберсенең парлагычлары бар.* В. И. Ленин.

ПАРЛАК *с. кит.* **1.** Яп-якты, нур чәчеп тора торган. *Парлак йолдыз.*

2. Атаклы, данлыклы, шанлы. *Сәмәрканд [4—5 гасырлар элек] мәдәниятнең иң парлак мәркәзе иде.* Шура. || Шәп, күркәм, күрекле. *Егет — дәрте белән көчле вә парлак.* Н. Арсланов.

3. Хыялга бай, күперенке фантазияле. *Әбием миңа көзнең караңгы кичләрендә Соңгур хан хакында бик парлак әкиятләр сөйли иде.* Аң.

ПАРЛА'МЕНТ *и.* Сайланган вәкилләр катнаша торган һәм дәүләт күләмендә законнар чыгарырга хокукы булган югарыгы җыелыш. *Парламентка сайлаулар үткәрү.* □ *Эшчеләр --- Ачлык походлары ясыйлар, Йөз тоталар мәшһүр йортларга, --- Ил тәкъдире кулларында булган, Власть торган парламентларга.* М. Гафури.

ПАРЛАМЕНТАР *с.* Парламенты булган (дәүләт системасы турында). *Парламентар республика.*

ПАРЛАМЕНТАРИЗМ *и.* Башында парламент тора торган буржуаз дәүләт системасы. *Сезгә конституция турында, парламентаризм турында сайрадылар.* Г. Ибраһимов.

ПАРЛАМЕНТЁР *и.* Сөйләшүләр алып бару өчен сугышучы якларның берсеннән икенчесенә җибәрелгән кеше. *Фашистлар, --- халыкара нормаларны бозып, безнең парламентёрларга аттылар.* С. Шакир.

ПАРЛАНДЫРУ *ф.* Парга әверелдерү; пар ясау. *Тозлы суны парландырып тоз алу (табу).* □ *Якуб абзый махсус парландыру камералары төзегән.* М. Хәсәнов.

ПАРЛАНУ I *ф.* **1.** Пар эчендә торып җылыну яки җебенү. *Мунчада парлану.* □ *Без үз тәнебездән чыккан тиргә үзебез парланып изрәгәнбез, хәлсезләнгәнбез.* М. Әмир.

2. Пар, бу чыгару, пар бөркеп тору. *Мулла, бер ике чынаяк эчкәч, парланып торган кайнар чәен бүлде.* А. Шамов. *Сәхрәләрдә йөреп кайткангамы — Парланып та тора пар атым.* Җыр. || Кояш нурлары астында җылынып сурыгу, кибенү (җир турында). *Пионерлар сабаннарын тирес астында парланып яткан, җылы кояш нурлары белән күпереп киткән туфракка батырдылар.* Г. Гобәй.

3. Һавадагы пардан хасил булган вак кына сыеклык тамчылары белән каплану (һәртөрле өслекләр турында). *Тәрәзә пыялалары парлану.* □ *Тыштан килеп кергәч, күзлек парлана да, бернәрсә дә күреп булмый.* Г. Камал.

4. Пар, бу белән тулу. *Бу өйгә самовар кергәнен хәтерләмим. --- Итле аш буы белән парлангандыр дип тә белмим.* Г. Ибраһимов.

ПАРЛАНУ II *ф. к.* парлашу I. *Парлылар йөри парланып, Без йөрибез зарланып.* М. Фәйзи. [*Без*] *парланып рәсемгә төштек.* Ә. Айдар.

ПАРЛАП-ПАРЛАП *рәв.* **1.** Пар-пар итеп, икешәрләп. *Аркылы колгага каен себеркеләре парлап-парлап асылган.* Г. Әпсәләмов.

2. Пар-пар булып (егет белән кыз һ. б. турында). *Урамда --- киенгән-ясанган кешеләр, матур кызлар, яшь ханымнар, офицерлар, яшь егетләр парлап-парлап йөриләр.* Г. Ибраһимов. [*Клубта*] *парлап-парлап биюләр башланды.* Ш. Камал.

ПАРЛАУ I *ф.* **1.** Кайнар суда (соңыннан пар чыгып торырлык итеп) пешекләп йомшарту. *Зур бакларда --- кайбер маллар өчен генә печән вагы парлыйлар.* Ә. Еники. || Парда дымландыру, дәмләү. [*Гөлҗамал:*] *Әтәчне дә йолыктым, пылау да парларга куйдым.* К. Тинчурин.

2. Мунча пары әсселегендә себерке белән чабу. || *күч. гади с.* Бик каты кыйнау, тәпәләү. — *Безне --- каеш чыбыркы белән парларга кирәк.* Һ. Такташ. || *күч. гади. с.* Тиргәү, шелтәләү, бик каты ачулану. *Пар сөрүне үз вакытында бетермәсәк, анысы өчен райком секретаре барыбызны да парлый.* Ф. Хөсни.

ПАРЛАУ II *ф.* **1.** Икешәрләп кую, берсе янына икенчесен — ишен өстәү, парлы итү. *Чынаякларны парлау.* □ *Шәмсекамәр егетләрне, кызлар белән парлап, түгәрәк ясап утырта.* А. Әхмәт.

2. *рәв. мәгъ.* **парлап.** Икәү бергә, икәүләшеп. *Хәмзә белән Рәхмәт парлап җырлыйлар. Шәми --- кушылгалап ала.* М. Фәйзи. || Парлашып. *Коймакка булгач парлап киләләр аны, Гали абзый.* Г. Әпсәләмов. *Өчтармакның суларында Аккошлар йөзә парлап.* Х. Садрый.

ПАРЛАУ III *ф.* Парга сөрү. *Сабан басуларын былтыр көз көне үк парлап, --- яз көне чәчеп калдырганнар иде.* Сов. әд.

ПАРЛАУ IV *ф. к.* парылдау (2 мәгъ.). *Нурлар парласын рәхмәт багында.* З. Бәшири.

ПАРЛАШУ I *ф.* **1.** Бер пар (егет белән кыз, ир белән хатын) хасил итү, пар булу. *Парлашып дөнья көтү.* □ *Кешеләр парлаша. Марс та өйләнде. Рива да очты инде.* Э. Касыймов. *Парлаштыгыбызның максаты — балалар тәрбия итмәк иде.* Шура.

2. *рәв. мәгъ.* **парлашып.** Бер пар булып, бер пар рәвешендә. [*Яшьләр*] *барысы да парлашып, тотынышып, зал буенча йөренә башлыйлар.* Г. Коләхметов. *Җирән айгырны җигеп, парлашып тарантаска менеп утырдык.* Ә. Айдар.

ПАРЛАШУ II *ф. гади с.* Ачуланышу, тиргәшү. *Парлашу парлашкач була.* Әйтем.

ПАРЛЫ I *с.* **1.** Пар чыгарып торган. *Парлы өйрә.* □ *Ике яшүсмер юеш, парлы тиресне чаналарына төйиләр.* Ә. Еники. || Пар катыш. *Ишекне ачуга, Шәмсинең борынына махорка төтене кушылган парлы җылы килеп бәрелде.* Г. Бәширов.

2. Эссе пары булган; парланырга мөмкин булган. *Парлы мунчага кереп, яшь каен себеркесе белән чабынсак, дөнья түгәрәкләнә инде.* М. Гали.

ПАРЛЫ II *с.* **1.** Пары белән, икешәрле. *Кар тирән түгел, агач араларында --- тасма төсле парлы сызыклар, чана эзләре күренгәли.* Ш. Камал. || Ирле-хатынлы. — *Бүген безнең парлы кунакка барасы булды.* Г. Камал. *Яшьләр юк диярлек, күбрәк парлы халык.* Ә. Еники.

2. Нәрсәне дә булса икәүләп эшләгән, икәүләп башкарган. *Биюләрдән соң ялгыз җыр, парлы җыр, тагын күмәк җыр тезелеп киткән иде.* Ш. Камал.

Парлы сүзләр — *к.* куш сүзләр.

ПАРЛЫК *и.* Пар, бер иш булу. *Зәңгәрсу киемнәренең парлыгы аларны апалы-сеңелле итеп таныта.* Ф. Әмирхан.

ПАРЛЫ-ПАРЛЫ *с.* Пар-пар (ир-хатын, егет-кыз, ике ахирәт һ. б.) булып йөрүче. *Киндер йомшартучылар*

парлы-парлы дүрт кыз булып чыкты. Г. Бәширов. | *рәв. мәгъ. Кеше йөри парлы-парлы, Без генә моңлызарлы.* Җыр.

ПАРМӘ-ПӘР *рәв.* Бик кызышып, һич бирешмичә (тиргәшү һ. б. турында). *Апа --- вагондагылар белән парма-пәр әрепләшергә тотынды.* А. Гыйләҗев.

ПАРНА *и. диал. к.* пар II. *Мин ике парна арасында, Гыйрфан байның ындырында, машина* [*молотилка*] *кордым.* Г. Ибраһимов.

ПАРНАС *и. кит.* Грециядә, имештер, музалар — шигърият алиһәләре яши торган тау исеме, поэзия символы. *Җыр — абелхәят чишмәсе, Ә миңа — алтмыш кына! Парнасның алтын кыясын Мин әле тапмыш кына.* Н. Арсланов.

ПАРНИК *и.* Яшелчә һәм җимешләрне иртә үстереп өлгертү яки аларның үрентеләрен үрчетү өчен төбенә тиресле туфрак салынган, өсте пыялалы рамнар белән каплап җылытылган чокыр рәвешендәге түтәл. [*Яшелчәләрнең*] *үрентеләре март урталарында ук инде парникларда баш калкыталар.* Г. Галиев. *Яз көне парникта үстерелгән кыярларның исе нинди тәмле!* Робинзон эзл.

ПАРОВОЗ *и.* Пар машинасы белән йөртелә торган локомотив. *Вокзал ягыннан --- сузып-сузып паровоз кычкырган тавышлар ишетелә.* Ш. Камал. *Паровоз Юдинодан соң кире борылачак, аннан эшелонны башка паровоз тагып китәчәк иде.* Г. Гобәй.

ПАРОВОЗЧЫ *и. к.* машинист.

ПАРО'ДИЯ *и.* 1. Берәр шәхеснең яки группаның эшен, үз-үзен тотышын, сүз яки язу стилен көлкеле итеп күрсәтә торган тамаша, кыланыш яки сатирик әсәр. *„Печән базары яхут Яңа Кисекбаш“ поэмасы --- иске Кисекбаш китабына пародия итеп язылган. Тукай борынгы поэманың үлчәвен, сюжет схемасын файдаланып, идея ягыннан пародия объектына капмакаршы әсәр тудыра.* И. Нуруллин. *Халык җыры пародиягә мохтаҗ түгел. Халыкның яхшы, матур җырына нигә пародия язарга?* Н. Юзиев.

2. *күч.* Кирәкле таләпләргә җавап бирүдән ерак торган, бик начар эшләнгән нәрсә; билгеле бер үрнәккә охшатырга тырышып та, бик начар чыккан эш. *Буржуаз суд — гаделлеккә пародия.* Афоризм.

ПАРОЛЬ *и.* Хәрби хезмәттә яки конспиратив оешмада үз кешеләрне тану өчен шартлы рәвештә алдан билгеләнгән яшерен сүз. *Домбровский --- көтүче картның исән булуын, ә парольнең яңа булуын әйтте. Гадәттәгечә исән-саулык сорашкач, „Ат югалды араннан...“ диясе. „Ишетмәдем, күрмәдем“ дияр. „Тоягында дагасы, колагында тамгасы...“ диясе. Шуннан соң көтүче йомышыңны сорар.* Ш. Маннур. || *күч.* Характерлы тышкы билге, шартлы билге. *Балыкчылар пароле — кармак сабын күрмәгәч, алар* [*малайлар*] *шигәйделәр, кармакларын, тезгечләрен җәһәт-җәһәт җыештырып, түбән таба китеп бардылар.* А. Гыйләҗев.

ПАРОМ *и.* Юлчыларны, йөкләрне һ. б. зур елгалар аша кичерү өчен бер ярдан икенче ярга йөреп тора торган зур палубалы махсус судно яки сал. *Печән төягән зур паром теге яктан бу якка чыгып килә.* И. Гази. *Паром туктый торган күпердә, кулына кармак сабы тотып. Салих утыра.* Г. Мөхәммәтшин.

ПАРОМЧЫ *и.* Паром йөртүче эшче. — *Бу вакытта паромчылар буламы соң?* Г. Әпсәләмов. | *с. мәгъ. Салкын җилдә йөзе уттай кызарган таза гына паромчы агай --- сәфәрчеләрне кисәтеп куйгалый.* Э. Касыймов,

ПАРОХОД *и.* Пар машинасы белән йөртелә торган зур судно яки кораб. *Диңгез пароходы. Пассажир пароходы.* □ *Зур бер пароход китәргә борылып маташа, пристаньдагы халыкның шау-шуы ишетелә.* Г. Бәширов. *Ярып Идел дулкыннарын Пароход килә.* Г. Хуҗиев.

ПАРОХОДЧЫ *и. иск.* Пароход хуҗасы, пароходлар тотучы капиталист.— *Булса да ул* [*налог*] *пароходчылар өчен генә булыр, сезнең бит пароходларыгыз юк.* Ш. Мөхәммәдев.

ПАРОХОДЧЫЛЫК *и.* Пароходлар йөртә, пароходлар белән идарә итә торган предприятие. *Агыйдел елга пароходчылыгы.* □ *„Балтика“ пароходчылык идарәсе урнашкан портка килеп җитте.* И. Низамов.

ПАР-ПАР *рәв.* Икешәрләп янәшә. *Кызылармеецлар киң юлның ике ягыннан пар-пар тезелешеп баралар.* Э. Еники. *Сайраса кош таңда торып, Талга кунып, пар-пар булып,* [*Бибкәйнең әнисе*] *балаларын Шул кошларга охшата.* Ш. Маннур.

ПАРТ- Кушма сүзләрдә „партиягә бәйләнешле“, „партияneke“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **партдисциплина, парткомиссия, партконтроль, партконференция, партстаж** һ. б.

ПА'РТА *и.* Мәктәп укучылары өчен утыргычы белән бергә беркетелеп ясалган авыш өсле өстәл. *Мәктәп классы. Парталар, кара такта. Уртада өстәл артында укытучы.* А. Әхмәт. *Иң алдагы партадан --- тырпаеп торган кызыл чәчләре өчен керпе кушаматы алган малай күтәрелде.* Г. Гобәй.

◇ **Парта арасыннан чыгу** — мәктәптә укып чыгу. — *Мин тартмыйм бит, Борһан ага. — Инде, парта арасыннан чыккач, ярый ул. Кабыз әйдә!* Р. Төхфәтуллин.

ПА'РТАДАШ *и.* Кем белән дә булса бер үк партада утыручы. *Партадашлар дуслыгы.* | *с. мәгъ. Сабир, әлеге партадашым Сабир да --- бер миңа, бер аңа* [*Рифаткa*] *карап куя.* Н. Исәнбәт.

ПАРТБИЛЕ'Т *и.* СССР Коммунистлар партиясендә член булып торуга таныклык билеты.

ПАРТБЮРО *и.* Башлангыч партия оешмасының сайлап куелган җитәкче органы. — *Партбюро сине --- агитатор итеп билгеләргә карар чыгарды.* Г. Әпсәләмов. || *сөйл.* Шул бюроның утырышы. — *Партбюрода мин сиңа укырга кирәклек турында сөйләдем.* Р. Ишморат.

ПАРТЕР *и.* Тамаша залының төп өлеше — урындыклар тезелгән авыш идән. *Фәтхулла хәзрәт, ложага кереп, партерда тезелгән кеше башларының куплегенә гаҗәпләнеп утырганда, кинәт звонок шалтырады.* Ф. Әмирхан. [*Фәхри*], *партер ишеге төбендә аягүрә басып тыгылган халыкны ерып, этеп, кысылакысыла фойега чыкты.* Г. Ибраһимов.

ПАРТИЗАН *и.* Илгә басып кергән дошман тылында үзлегеннән оешып, мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итә торган хәрби отряд сугышчысы, халык сугышында катнашучы. *Хезмәт ияләренең алдынгы өлеше, партизан отрядларына оешып, Кызыл Армиягә ярдәмгә чыкты.* Г. Гобәй. *Ә алачык безнең штаб иде, Партизаннар идек без анда* [*урманда*]. Ә. Ерикәй. | *с. мәгъ. Күк чардуган белән уратылган... Партизан кыз ята кабердә.* З. Мансур.

ПАРТИЗА'НКА *и.* Партизан хатын-кыз. *Ант иткән ул — партизанка — Дошманнарны кисәргә.* Г. Кутуй. *Партизанка хәзер, корал тотып, Украина бакчалары кабат Чәчәк атсын өчен көрәшә.* Г. Хуҗиев.

ПАРТИЗАНЛЫК *и.* 1. Партизан булу, партизан тормышы. *Партизанлыкта йөрү.* □ [*Каравылчы*], *яшьләр белән рәттән Партизанлык итеп, якты тормыш өчен сугышты.* Ә. Исхак. *Немецлар кергәч, бөтен авыл партизанлыкка китә.* Г. Гобәй.

2. *күч. сөйл.* Югары инстанцияләр белән сөйләшмичә, киңәшмичә, килешмичә үз белдегең белән эш итү; башбаштаклык.— *Кешеләрне --- үзебез телгәнчә атып бәрә башласак, мондый партизанлыкның*

безгә кыйммәткә төшүе ихтимал. Ф. Хөсни. *Оешманлык һәм партизанлык тупаслыгын инде тәмам ватарга кирәк безгә.* Ә. Баянов.

ПАРТИЗАННА'РЧА *рәв.* 1. Партизаннар кебек. *Партизаннарча сугышу.* □ *Партизаннарча киенгән кара күзле чандыр кеше аңарда [Хәсәндә] бернинди дә шик кузгатмады.* А. Расих.

2. Башбаштаклык, партизанлык (2 мәгъ.) белән мавыгып. *Мәсьәләне партизаннарча үз белдегең белән хәл итү.*

ПАРТИЗАНЧЫЛЫК *и.* 1. Партизаннарча (2 мәгъ.) эш итү (сугышу һ. б.) күренеше. *„Хәрби оппозиция" армиядә партизанчылыкны яклый һәм регуляр Кызыл Армия төзүгә каршы иде.* СССР тарихы.

2. *күч. к.* партизанлык (1 мәгъ.).

ПАРТИТУ'РА *җый. и.* Күп тавышлы музыкаль әсәрдәге барлык партияләр җыелмасы. *[С. С. Бергольц] оригиналь операларның партитураларын җиренә җиткерү буенча ныклы эшкә кереште.* М. Җәлил. *Хәбир, театрда сезон ачылып, репетицияләр башланганчы, партитураны төгәлләргә уйлады.* Ш. Хөсәенов.

ПА'РТИЯ *и.* 1. Иҗтимагый сыйныфның иң алдынгы, актив өлешен үзендә туплаган һәм шул сыйныф интереслары өчен башка, дошман сыйныфлар белән көрәшкә җитәкли торган киң масштаблы политик оешма, сыйнфый оешмаларның иң югарыгы төре. *Безнең юлбашчыбыз — Коммунистлар партиясе бөтен СССРны мәктәпкә әйләндерде.* Һ. Такташ. || Советлар Союзы Коммунистлар партиясе турында.— *Колхоз партия оешмасы. Партиягә [партия сафына] керү [язылу]. Партиягә турылыклы булу.* □ *Сугыш беткәч, мин партия тарафыннан Мәскәүгә институтка укырга җибәрелдем.* Г. Ибраһимов.

2. Уртак теләк, уртак фикер нигезендә берләшкән кешеләр төркеме. *Моңарчы кабилә, партия талашын онытып, бары бергә кайнашкан казакълар, атка менеп далага чыгу белән, --- тагын үз хәлләренә кайттылар.* Г. Ибраһимов.

3. Группа, отряд, төркем. *Кыскасы, җир катлауларының структураларын картага төшерү өчен чыгарылган партия үз алдына куелган бурычын уңышлы башкарып кире кайтырга чыккан вакытта, Миләүшә Тәбәнәкевкә бөтенләй гашыйк иде инде.* М. Әмир.

4. Беришле предметларның яки бер категориягә кергән шәхесләрнең (җан ияләренең) беркадәр сандагы группасы. *Бер партия товар. Бер партия терлек.* □ *[Ике хәрби кеше] үзләре белән бер партия яралылар алып чыкканнар, аларны больницага салырга кирәк икән.* И. Гази.

5. *муз.* Күп тавышлы яки күп кешеләр тарафыннан башкарыла торган музыкаль әсәрдә аерым бер инструментның яки аерым бер башкаручының өлеше. *Муса --- операладагы музыкаль партияләрнең ничек башкарылуы белән кызыксына иде.* Ш. Маннур.

6. Уеннын (карта, шахмат һ. б.) тәмамланган, бөтен бер уйналышы. *Безнең партия тәмам булып, студентның унбер сум җитмеш өч тиен отканлыгы заһир [билгеле] булды.* Ф. Әмирхан.— *Әйдә әле, бер партия шахмат уйнап җибәрик.* Т. Гыйззәт. *Фәхри аның [Гөлнурның] тупларны кире кагу осталыгына сокланып туя алмады һәм партияләрне берсе артыннан берсен оттыра барды.* Г. Әпсәләмов.

ПА'РТИЯДӘШ *и.* Кем белән дә булса бер үк партиядә (политик оешмада яки группада) торучы. *Давыт һәм аның партиядәшләре --- яңа эш күрсәткәннәр.* Г. Нигъмәти.

ПА'РТИЯЛЕ *с.* 1. Партиядә (Коммунистлар партиясендә) член булып торучы. *Партияле яшь инженер Габбас югары сыйфатлы мех эшләүнең химик ысулларын табуы өчен бүләкләнергә тиеш.* Г. Нигъмәти. *Фазылҗановка иң яхшы тәэсир ясаганы — партияле һәм партиясез интәшләрнең аңа ышанычны өзмәве булды.* Ф. Хөсни. | *и. мәгъ.— Күрдем, комсомоллар белән партиялеләр җыелышын уздырып яталар.* Т. Гыйззәт.

2. Партия интересларыннан чыгып, партия өйрәткәнчә эш итә торган, партиячел. *Сәнгатькә [хезмәткә] партияле мөнәсәбәт.* □ *Әдәбият — партияле ул, гомумпартия эшенең аерылмас бер өлеше ул.* Г. Иделле.

ПА'РТИЯЛЕЛЕК *и.* Партияле (2 мәгъ.) булу сыйфаты. *Социалистик реализм марксизм-ленинизмга таяна, коммунистик партиялелек исә аның җаны.* И. Нуруллин.

ПА'РТИЯСЕЗ *с.* 1. Партия члены булмаган. *Безнең эшче-крестьян кызылармеецның бик күбесе партиясез.* Ш. Камал.— *Партия тарафыннан җаваплы эшкә куелган кеше булгач, гәрчә ул партиясез булса да, мин аңа бик ныклы ышана идем.* Р. Ишморат.

2. Партия интересларыннан чыгып эшләнмәгән, битараф. *Партиясез әсәр безгә кирәкми.* М. Җәлил.

ПА'РТИЯСЕЗЛЕК *и.* Битарафлык, иҗтимагый идеяләргә, сыйнфый көрәшкә катнашмау. *Империалистлар --- „сәнгатьнең партиясезлеге", „иҗатның абсолют иреклелеге", идеясезлек кебек ялган концепцияләрне безнең җәмгыятькә сөйрәп кертергә маташалар.* Сов. әд.

ПА'РТИЯЧЕЛ *с.* Партия идеологиясенә, эшенә, интересларына бирелгән, шуңа турылыклы. *Партиячел кеше. Партиячел матбугат.*

ПА'РТИЯЧЕЛЕК *и.* Билгеле бер партия яклы булу, шул партия интересларына эзлекле рәвештә турылыклы булу. *Буржуа теоретиклары сәнгатьтән партиячелекне куып, форманы гына нигез итеп алырга маташалар.* Һ. Такташ. *[Сәнгатьтә] безнең --- партиячелек чынлыкны дөрес чагылдыруны тәэмин итә.* М. Җәлил.

ПАРТКАБИНЕТ *и.* КПСС комитетлары карамагында партия мәгарифе кабинеты. *Парткабинетка яңа газета-журналлар килгәндер.* Э. Касыймов.

ПАРТКОМ *и.* 1. Партиянең урындагы комитеты. *Партком утырышы. Партком бүлмәсе.* □ *[Гәрәй] парткомга барса, анда зур вакыйга: партия комитеты җыелырга тиешле бүлмәне --- атлы жандармнар камап алган.* Г. Ибраһимов. || Шундый комитет урнашкан бүлмә. *Партия члены булмасам да, партком ишеге минем өчен дә ачык бит.* Р. Ишморат.

2. *сөйл.* Партия комитеты секретаре.— *[Сафаровның] теориясен, иптәш партком, бәлки сез аңларсыз?* Ш. Камал.

ПАРТНЁР *и.* 1. Кем белән дә булса бер уенда яки уенчыларның бер үк командасында уйнаган кеше. *Монда еш кына шашка уйнап маташа иделәр ---. Солдат яхшы уйный. Шәрәфи агай[ның] яхшы партнёры читкә җибәрәсе килми.* Ш. Камал.

2. Сәхнәдә яки аренада, спорт уеннарында һәм биюләрдә бергә катнашкан пардаш. *Кариев үзе башкара торган рольнең текстын яттан белү өстенә, партнёрның (каршы уйнаучының) текстын да үзләштерә.* И. Рәмиев. *Мин Яго ролендә чыгыш ясадым һәм Отелло ролендәге татар трагигы Мохтар ага Мутин белән партнёр булдым.* Х. Сәлимҗанов.

3. Аралашып, билгеле бер мәнәсәбәтләргә кереп йөргән як. *Фирманың сәүдә партнёрлары.*

ПАРТОЕШМА *и.* КПССның урындагы оешмасы. *Партоешма утырышы. Партоешма карары.* □ *Партоешма секретаре Дускаевны район үзәгенә ниндидер киңәшмәгә чакырып алганнар.* Ә. Еники.

ПАРТОРГ *и.* Партия оешмасы бүлекләрендә җитәкче итеп сайлап куелган җаваплы кеше.—*Коммунистлар*

барлык сугышчыларга үрнәк күрсәтергә тиешләр,— диде парторг Соловьев. Г. Әпсәләмов.

ПАРФЮМЕР *и.* 1. Парфюмерия өлкәсендә эшләүче кеше.

2. *с. мәгъ.* Парфюмериягә караган, шуңа бәйләнешле. *Парфюмер товарлары сатыла торган кечкенә киоск янында бер хатын тора.* М. Хәсәнов.

ПАРФЮМЕ'РИЯ *и.* 1. *җый.* Гигиеник һәм косметик максатлар өчен файдаланыла торган нәрсәләр (ислемай, одеколон, сабын һ. б.); косметик товарлар.

2. Эшләп чыгаруның шундый продуктлар җитештерә торган тармагы.

ПАРЧА I *и.* 1. *иск.* Бөтеннең бер кисәге, ярчык. *Таш парчасы. Ядрә парчасы.*

2. Берәр әйбернең үрнәге итеп алынган кечкенә кисәк, өлеш.— *Менә, җәмәгать, сачәргә җир бирмәсәләр дә, күзләрегезгә сөрмә кылып тартырга берәр парча туфрак алып кайттым.* Ш. Мөхәммәдев.

3. *күч.* Югары осталык белән язылган кыска әсәр— кечкенә шигырь яки хикәя. *„Бер нәүхә" исемендәге шушы парчалар --- империалистлар сугышы вакытында язылган иде.* М. Гафури. *Шагыйрьнең [Ш. Маннурның] сугыш елларында язылган лирик парчалары, баллада, поэма һәм шигырьләре „Еллар моңы" исемле җыентыгында басылдылар.* Х. Хәйри. || Гомумән зур булмаган басылган әсәр, публикация. *Казаннан чыттәге яшьләр Кавине аның әсәрләре, әдәби парчалары белән публицистик мәкаләләре аша беләләр.* Г. Нигъмәти.

ПАРЧА II *и.* 1. Тукыма өстенә чигеп, чүпләмләп һ. б. ясалган яки төшерелгән бизәк — телле-телле орнамент, чәчәк-яфрак рәсемнәре. *Тик менә мин алачак күлмәкләрнең парчасы нинди, ягъни аңа нинди рәсемнәр төшерелгән булырга тиеш — шушы мәсьәләдә аптырабрак калдым.* Г. Галиев. *Аклы яулыкның парчасы һәрбер яулыкта булсачы.* Җыр. || *күч.* Тигез төстәге өсйөздә, җирлектә матур булып аерылып торган башка төстәге таплар. *Хәнифә кызарып китте, беләүләнеп янган битендә алсу парчалар хасил булды.* Сов. әд.

2. Алтын яки көмеш белән чигелгән, путаллы орнамент төшерелгән тукыма. *Кояш иңгән офыкта бөдрәләнеп торган сыек болытлар, алтын парчалар төсле, күз камаштырырлык ачык алсу нурга манчылганнар.* Ш. Камал. *Марко кайта каладан, --- Асрау хатынга чепчиклык, Кыйммәтле парча алган.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Парча камзул.*

ПАРЧАЛАНУ *ф.* 1. Вак кисәкләргә аерылу, телгәләнү. *Парчаланып беткән күлмәк.*

2. *күч.* Газап чигү, рухи газаплану, өзгәләнү (йөрәк, күңел һ. б. турында).— *Сине үз балам кебек күрүче идем, киткән вакытыңда күрми калгач, йөрәгем парчаланды.* Г. Ибраһимов. *Йөрәкнең кискен тойгылар белән парчаланасы, каты көрәшләргә омтыласы килә.* Ш. Камал.

ПАРЧАЛАУ I *ф.* 1. Бозу, җимерү; челпәрәмә китерү, парә-парә китерү.

2. *Йөрәк, күңел* сүзләре белән килгәндә: өзгәләү, газаплау.— *Күңелем[не] парчалама, Арслан абыем, мине кызган син.* Ә. Фәйзи.

ПАРЧАЛАУ II *ф.* Парчалар II (1 мәгъ.) төшерү, парча белән бизәү. *Җәймәне парчалап чигү.* || *күч.* Телле-телле таплар төшерү. *Этәч --- аягына буялган катык белән идән сайгакларын парчалаган.* Г. Галиев.

ПАРЧАЛЫ *с.* Парча II (1 мәгъ.) төшерелгән яки парчалап чигелгән. *Өстендәге парчалы күлмәге дә, билләрен кысып торган ак альяпкычы, --- яулыгы да үзенә шундый килешеп тора аның [Галиянең].* М. Шәрифуллин. *Аккош алды, суга салды Парчалы паласымны.* Җыр.

ПАРЧА-ПАРЧА *с.* Кисәк-кисәк. *Парча-парча ука.* | *рәв. мәгъ. Яллы бүре --- ак-күк атны парча-парча өзгәләп ыргытты, ди.* Х. Кәрим.

Парча-парча булу (килү) — 1) челпәрәмә килү, уалу. *Бутылка --- лампага бәрелеп парча-парча булды.* Ш. Мөхәммәдев; 2) парә-парә булу. *Янды, көйде, парча-парча булды мескен күкрәгем.* Ш. Бабич.

ПАРЫЛДАУ *ф.* 1. Тавышланып җилфердәү. *Ал әләмнәр каберем өстендә парылдасын.* С. Сүнчәләй.

2. Ялкынлану, ялтырау. *Парылдап янган ут.* || Япякты булып күренү. *Кояшка парылдап тора торган ул тирмәләрдә кымыз да бик тәмле була, имеш.* Аң.

ПАРӘ *и. иск.* 1. *Йөрәк, күңел* һ. б. сүзләр белән килгәндә: иң кадерле нәрсә, иң кадерле өлеш. *Баламның баласы — күземнең карасы, йөрәгем парәсе.* Мәкаль. *Бу гыйлыклыкның бәласе — янды бәгърем парәсе.* Г. Сәмитова.

2. Ятлана яки ритуал буенча укыла торган китапның махсус билгеләнгән өлешләреннән берсе. *Хәммад хажи угълы Садыйкны --- унбер яшьләренә җиткәндә тугыз парә коръән бикләткән иде.* Г. Газиз. *Ястүдән соң бер парә коръәнен тәмам итеп, Фатыйма бикә дә рәхәт йокыга бирелә.* Г. Ибраһимов.

3. Табышның кемгә дә булса бирелә, бүләк ителә торган өлеше. *Кара халык ачлыктан үлеп бара, Боларны туйдырырга юктыр парә.* Ш. Мөхәммәдев.

ПАРӘ-ПАРӘ *рәв.* Кисәк-кисәк; күп өлешләргә бүлгәләп. *Парә-парә кисү (турау).* □ *Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, Парә-парә телмәсә гыйшык-мәхәббәт кайчысы.* Г. Тукай.

Парә-парә булу (килү, китерү) — 1) челпәрәмә килү (китерү). *Зур көзге булды шунда парә-парә.* М. Гафури; 2) газап чигү (чиктерү) турында. *Һай, бу бала дигәннәре! Йөрәкләрне парә-парә китерә бит.* Ш. Хөсәенов.

ПАС *и. спорт.* 1. Тупны үз командандагы берәр уенчыга тапшыру. *Пас бирү.*

2. Карта уенында җиңелү билгесе итеп әйтелә торган сүз.— *Козырь — капут! — диде генерал.— Мин пас инде! — диде адмирал.* Х. Туфан.

ПА'СКВИЛЬ *и.* Яла ягып язылган язу. *Нургали --- биш-алты битле кулъязма китереп салды: — Менә шушы пасквиль белән танышып чыгыгыз әле.* М. Хәсәнов. *Карт ишан яңача укытуның зарары турында бер пасквиль яза.* М. Мәһдиев.

ПАСЛЁНЧАЛАР *күпл. биол. и.* Бәрәңге, помидор, тәмәке һ. б. керә торган семьялыктагы үсемлекләр. *Кызыл борыч паслёнчалар семьялыгына керә.* Робинзон әзл.

ПА'СПОРТ *и.* 1. Шәхесне таныта торган рәсми документ. [*Немец офицеры*] *өстәл тартмасыннан Франц Мюллер исеменә язылган немец паспорты чыгарып сала.* Г. Гобәй. *Мин ерактан килдем, менә сезгә паспорт.* К. Нәҗми.

2. Берәр төрле машина, җиһаз һ. б. ш. нәрсәләрнең кайда эшләнгәнен, кайда регистрацияләнгәнен һ. б. белдерә торган документ. *Станок паспорты. Автомобиль паспорты.*

ПАССАЖ *и.* 1. Сәүдә пунктлары урнашкан ябулы галерея.— *Пассажга чыгам, алтын алка, брошкалар алам.* Ш. Мөхәммәдев. *Шәраф --- пассаждагы хуҗалык әйберләре магазинына кереп китте.* Г. Минский.

2. Китап, мәкалә яки нотык текстының стиль, тема һ. б. җәһәтеннән аерылып торган бер өлеше. *Романга [„Ут һәм су" романына] стиль берлеге җитми. Аллегорик манерда язылган бүлекләр публицистик пассажлар белән чиратлаша.* Р. Мостафин.

3. Югары ноталардан түбәннәренә һәм киресенчә эзлекле рәвештә күчүнең тиз-тиз чиратлашуыннан гыйбарәт булган музыкаль фраза, музыкаль әсәрнең бер өлеше. *Остаз Хәбирнең шактый кыю һәм кызыклы эшләнгән полифоник комбинацияләренә, пассажларына булган соклануын яшермәсә дә, йомшак җирләрен табып торды.* Ш. Хөсәенов.

ПАССАЖИР *и.* Поездда, пароходта һ. б. ш. транспорт төрендә утырып баручы кеше. *Вокзал. Носильщиклар. Чемоданнар. Халык. Пассажирлар. Вагоннар.* Э. Ерикәй. || *с. мәгъ.* Юлчылар өчен билгеләнгән һәм махсус җиһазландырылган. *Пассажирлар бүлмәсе (залы, салоны).* □ *Ул [кызылармеец] пассажир вагонарының берсенең баскычына утырган.* Г. Гобәй.

ПАССАТ *и.* Гел бер юнәлештә озак вакыт исә торган җил — кайбер географик өлкәләргә хас. *Җәйге пассат. Төньяк-көнбатыш пассат.*

ПАССИВ *с.* **1.** Бурычларның артуына китерә торган. *Пассив сәүдә. Тышкы сәүдәнең пассив балансы.*

2. Хәрәкәтчән, эшчән булмаган; *киресе:* актив. *М. Гафури әсәрләрендәге ярлылар — байлар ишек төбендә мескен булып сыкранып торган көчсез, зәгыйфь, пассив кешеләр.* М. Җәлил. | *рәв. мәгъ. Пассив яшәү аның [шагыйрьнең] табигатенә дошман.* Г. Кашшаф.

3. Битараф рәвештә, берәр эшкә, шөгыльгә, көрәшкә һ. б. ш. катнашмыйча гына башкарылган. *Г. Ибраһимовның көтүчеләре, ялчы картлары байлар рәхәтенә каршы пассив ачу саклыйлар.* Г. Нигъмәти.

ПАССИВЛАШУ *ф.* Пассив булып китү, активлыкны, хәрәкәтчәнлекне югалту. *Әгәр тәнкыйтьчеләребез чыннан да пассивлашканнар икән, моның сәбәпләре нәрсәдә дип уйлыйсыз?* Каз. утл.

ПАССИВЛЫК *и.* Пассив (2 мәгъ.) булу, хәрәкәтсезлек. *Тукай иҗатында халыкның пассивлыгына ачыну, аның көрәшкә күтәрелүен күрергә теләү очракларын күплэп китерергә мөмкин.* И. Нуруллин.

ПА'СТА *и.* Камыр сыман масса рәвешендә чыгарыла торган кулинар яки косметик продукция. *Пар баскычлардан иңнәренә сөлгеләрен ташлаган, кулларына сабын, теш щеткасы, пасталар тоткан кызлар төштеләр.* И. Салахов.

ПАСТЕЛЬ *и.* **1.** Буяу порошогыннан прессланып ясалган йомшак карандаш.

2. Рәсем сәнгатендә шундый карандаш белән төшерелгән рәсем.

ПАСТЕРИЗА'ТОР *и.* Пастеризацияләү коралы (аппараты).

ПАСТЕРИЗА'ЦИЯ *и.* Азык-төлек продуктларын зарарлы микроорганизмнар үләрлек, ләкин тәме, туклыклылыгы бозылмаслык дәрәҗәдә җылыту.

ПАСТЕРИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Пастеризация ясау. *Җилэк-җимеш пастеризацияләү.*

ПАСТЕРНАК *и.* Зонт чәчәкләләр семьялыгыннан аш тәмләткеч сыйфатында файдаланыла торган сары чәчәкле үлән—кыргый хәлендә дә, яшелчә буларак та үсә. *Дрекмән кишерне, петрушканы, пастернакны алыштыра алырлык бик яхшы азыктамыр бирә.* Робинзон эзл.

ПАСТИЛА *и.* Шикәрләп пешерелгән җиләк-җимеш измәсе һәм шуннан ясалган конфет.

ПА'СТОР *и.* Протестант рухание.

ПАСТОРАЛЬ *и.* Көтүчеләр тормышын гади һәм бәхетле итеп, идеаллаштырып күрсәтә торган шигырь.

ПА'СХА *и.* **1.** Христианнарда һәм яһүдиләрдә язгы дини бәйрәм. *Пасхада чиркәү-колокол тавышыннан туйдык инде.* Ш. Мөхәммәдев. *Март вә апрель айлары керә. Пасха бәйрәме башлана. Шул вакыт --- һәр елны балаганнар корыла.* Г. Ибраһимов.

2. Эремчек кушып пешерелгән татлы күмәч. *Пасха ашау.*

ПАТ *и.* Шахмат уенында уенчыларның берсе королен шах астына куймыйча бер фигурасы белән дә йөри алмый (йөреш кагыйдәгә сыймый) һәм шуна күрә уен уртак исәпкә тәмамлана торган очрак. *Мат куям дип патка китерү.*

ПАТЕНТ *и.* **1.** Уйлап табучының авторлык хокукы турында таныклык.

2. *иск.* Берәр аерым эш (сәүдә һ. б.) белән шөгыльләнергә хокук һәм шундый хокук турында документ. *Исәбе — патент алып, капка түбәсенә „Чүлмәк сатучы Шәвәли Габтелмәликов" дип язулы такта куярга, үзенең шөһрәтен ерак җибәрүдә иде.* С. Рафиков.

ПАТЕНТЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* патентлау.

2. *күч. с. мәгъ.* **патентланган.** Билгеле бер максат яки урын өчен бөтен ягы белән килгән, ярый торган. *Хафаланма, Нургали, --- беребез дә патентланган парторг булып тумаган.* М. Хәсәнов.

ПАТЕНТЛАУ *ф.* Нинди дә булса берәр ачышны, уйлап табуны рәсми рәвештә, патент биреп тану яки таныту. *Госманның --- югары сыйфатлы саф гипосульфат җитештерү технологиясенә караган уйлап табуын хәтта чит илләрдә дә патентламакчылар.* Э. Касыймов.

ПАТЕНТЛЫ *с. иск.* Сәүдә яки һөнәрчелек белән шөгыльләнергә хокукы (хокук документы) булган. *Патентлы сәүдәгәр.*

ПА'ТЕР *и.* Католик рухание.— *Минем камерага бер католик рухание килеп йөри, патер Курытко,— диде Лангфредини.* Ш. Маннур.

ПАТЕ'ТИК *с.* Дәрт, ярсу, дулкынлану белән сугарылган. *Патетик нотык. Патетик шигырь.* □ *—Әхмәт Фәйзи Ленинград эпопеясын „Туу сулышы" исемле патетик поэмада чагылдыры.* Г. Кашшаф.

ПАТЕ'ТИКА *и.* Патетик тәгъбирләнеш, дәртле, ярсулы хисләр чагылышы (берәр сәнгать әсәрендә, сөйләмдә һ. б.). *[Тукай шигырьләрендә] салкын канлы риторика түгел, ә көрәш сафларында шаулап, кукрәп килүче яшьләрнең йөрәгенә кайнар дәрт һәм өмет өстәүче патетика, ялкынлы илһам бар.* Г. Халит. || *күч.* Ачыну, тавышлану.— *Кемгә карый бу хәтле кайнар патетика? Кемне шулай ныклап яратмыйсыз?* Ш. Маннур.

ПАТЕФОН *и.* Махсус пластинкага язылган авазларны кабат чыгара торган аппарат. *Клубның аргы башындагы бүлмәсендә патефон уйнаталар.* А. Шамов.

Патефон бору — 1) патефон пластинкасын әйләндерә торган пружинаны махсус ачкыч белән бору. *Караңгыда кулга әләккән беренче пластинканы куеп, патефон борып җибәрдем.* Й. Гази; 2) *күч.* патефонны эшләтү (уйнату).

ПАТОГЕНЕЗ *и.* Берәр авыруның килеп чыгу һәм көчәю процессының эзлеклелеге һәм шул эзлеклелек закончалыкларын өйрәнә торган фән бүлеге. *Кызамык патогенезы.*

ПАТО'ЛОГ *и.* Патология белгече.

ПАТОЛО'ГИК *с.* **1.** Патологиягә бәйләнешле, патологиягә караган. *Патологик анатомия.*

2. *күч. кит.* Авыру нәтиҗәсендә килеп чыккан, нормаль булмаган. *Кешелеккә патологик нәфрәт.*

ПАТОЛО'ГИЯ *и.* **1.** Организмдагы авыру процессларын өйрәнә торган фән.

2. *күч. кит.* Нормаль булмаган хәл яки күренеш.

ПАТРИАРХ *и.* **1.** Ыруг башлыгы булып саналган ир кеше (гадәттә карт бабай).

2. Нинди дә булса коллективта иң хөрмәтле, иң өлкән шәхес. *Рус әдәбияты патриархы Лев Толстой.*

3. Христианнарда дин башлыкларының иң югары титулы.

ПАТРИАРХАЛЬ *с.* 1. *тар.* Патриархатка бәйләнешле, патриархат чорына карый торган. *Патриархаль җәмгыять.*

2. *күч.* Иске, консерватив йолаларга нигезләнгән. *Патриархаль тәртип.* □ *М. Гафуриның өченче иҗат мотивы — патриархаль-феодаль мөнәсәбәтләргә каршы көрәшү.* М. Җәлил.

ПАТРИАРХАЛЬЛЕК *и.* Патриархаль гореф-гадәт.

ПАТРИАРХАТ *и.* Ыруглылык иҗтимагый төзелеше чорының хуҗалыкта һәм җәмгыятьтә ирләр зуррак роль уйнаган дәвере (матриархаттан соң килә).

ПАТРИОТ *и.* Үзенең туган җирен, халкын, илен, ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше. *Бу кеше кыска гына вакыт эчендә үзен чын патриот итеп таныта алды.* Г. Гобәй. | *с. мәгъ. Кәлүч агай үзе туган җирен бик сөюче патриот бер адәм.* Ш. Мөхәммәдев. || Үзенең коллективы, оешмасы, группасы һ. б. өчен кайгыртучан кеше. *„Чулпан"га өстен чыгарга кирәкме? Кирәк! Үз колхозыңның патриотымы син, түгелме?* Г. Бәширов. *Алар [шәкертләр] үз мәдрәсәләренең патриотлары икәнлекләрен күрсәттеләр.* Ә. Фәйзи.

ПАТРИОТИЗМ *и.* Патриотларга хас булган күренеш (эш, теләк, хис); үз иленә, халкына мәхәббәт. *Совет патриотизмы.* □ *Патриотизм --- кешене шәхси курку хисләреннән өстен күтәрә.* М. Җәлил.

ПАТРИОТИК *с.* Патриотларга хас. *Патриотик традиция. Патриотик хисләр.* □ *Бөек Ватан сугышы чорында М. Укмасый патриотик рухлы шигырьләр бирде.* М. Гайнуллин.

ПАТРИОТЛЫК *и.* 1. Патриот булу. [*Солдатларның*] *поход җырлары --- патриотлыкның гүзәл үрнәге булып тора.* К. Нәҗми.

2. Патриотларча эш, чыгыш; патриотизм. *Патриотлык күрсәтү.* □ *Нигә безнең бер патриотлыгыбыз да юк, бер оешмабыз да юк,— ди [егет]. Бик кыю эшләр башкарасы килгән кешедәй сөйләшә.* Ш. Маннур.

ПАТРИЦИЙ *и.* 1. Борынгы Римда привилегияле катлау кешесе.

2. Урта гасырларда Германия шәһәрләрендә шәһәр аристократиясе вәкиле.

ПАТРОН I *и.* Эченә дары тутырылган һәм пуля яки ядрәләр белән бөкеләнгән гильза. *Аяк астында буш гильзалар, атылмаган патроннар, ак саплы гранаталар ауный.* И. Гази.

ПАТРОН II *и.* 1. Борынгы Римда ярлы-ябагайны үз канаты астына алган бай кеше.

2. *күч.* Тәрбияче, опекун.

ПАТРОНАЖ *и. к.* Патронат (1 мәгъ.).

ПАТРОНАТ *и. иск.* 1. Патрон II (1 мәгъ.) булу, кемне дә булса яклау, канат астына алу хәле.

2. Ярлы-ябагай балаларын тәрбияләү белән шөгыльләнүче учреждение. *Әхмәт [Фәйзи] 1924 елларда Уфада һөнәр патронатында яшәгән.* Ф. Хөсни.

ПАТРОНИМИК *с.* Атасының исеме буенча йөртелгән. *Татар әдипләреннән Муса Акъегетзадә үзенең патронимик фамилиясен таҗик-фарсы телендә „улы" төшенчәсендә йөрүче „задә" сүзен куллану юлы белән ясаган.* Каз. утл.

ПАТРОНТАШ *и.* Патрон йөртү өчен патрон оялары булган махсус сумка яки тасма. *Брезент сумкаларга, патронташларга әле генә өләшенгән патрон салынды.* Г. Бәширов. *Иңбашта мылтык, Билдә патронташ, Тик тәвәккәллек Аучыга юлдаш.* Н. Арсланов.

ПАТРУЛЬ *и.* Хәрби частьтан, милициядән һ. б. берәр урында гомуми тәртипне сакларга җибәрелгән отряд, коралланган кешеләр группасы яки кораб, самолет һ. б. *Хәрби патруль.* □ *Патрульләр берничә мәртәбә туктатып [миннән] пропуск сорадылар.* А. Шамов. || *сөйл.* Патруль группасы члены (берәр кеше, кораб, самолет). *Патруль үз юлына, Сөләйман үз юлына аерылышып киттеләр.* К. Тинчурин. | *с. мәгъ. Патруль катер. Патруль җайдак.*

ПАТРУЛЬЛЕК *и.* Патруль вазифасы. *Факультетның дружиначы егетләре белән Алмаз паркка патрульлек итәргә чыккан.* Б. Камалов.

ПАТША *и.* 1. Илдә хөкүмәт һәм гаскәр башлыгы булып саналган, чикләнмәгән хакимлеккә ия булган кеше, монарх. *Солдатлар кырыла, ә патшалар, халыктан яшеренеп, бер-берләренә кунакка йөриләр икән.* Т. Гыйззәт. *Патшалар барысы да диннең зур таянычы алар.* А. Алиш. || Мәскәү дәүләтендәге һәм соңрак Россия империясендәге монарх. *Патша самодержавиесе. Патша Россиясе. Патша хөкүмәте.* □ *Хәзер бөтен Россиядә патшага каршы сугыш бара.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Билгеле бер урында, җәмгыятьтә, мохиттә төп көч һәм хөкемдар булып торучы шәхес (яки шәхес итеп күз алдына китерелгән башка нәрсә). *Умартада корт анасы патша була.* Ш. Бабич. *Шәрип --- зур авылның үзәк мәхәлләсендә ялгызы патша булырга теләде.* Г. Ибраһимов. *Сусый иде шулай Дон буйлары, Патша иде монда корылык.* З. Мансур. || *ирон.* Хуҗа, башлык. — *Әһә! Әләктеңме, бозаулар патшасы [көтүче малай]!* Ә. Айдар.

3. *күч.* Үз төрендә иң күренекле булган нәрсә. *Арыслан — хайваннарның патшасы.* Мәкаль. *Син [скрипка] генә иң нечкә хисләр, Нечкә моңнар чишмәсе, Син тавышлар казнасы һәм Син уеннар патшасы.* Ш. Бабич. *Беранже „Француз поэзиясенең патшасы" дип исемләнгән.* Н. Юзиев.

ПАТШАБИКӘ *и.* 1. Патша хатыны. *Патша яки патшабикә туган көнне әленә торган флаг сабын чорма тәрәзәсеннән чыгарып, утызлы лампа элеп куйганнар.* Г. Гобәй.

2. Хатын-кыз патша. *Пётрдан соң тәхеткә килгән патшабикәләрдән Екатерина Беренче заманында бу эш [китап басу] сүнә.* И. Рәмиев.

ПАТШАЛАРЧА *рәв.* Патшаларга охшашлы, патшаларга хас булганча. *Өстәл иң затлы азыклар белән сыгылып тора. Патшаларча.* Р. Төхфәтуллин.

ПАТШАЛЫК *и.* 1. Патша булу вазифасы, патша дәрәҗәсе. *Патшалыктан төшерелү.* □ *Бер көн патшалык — ул да патшалык.* Мәкаль. || Хөкемдар, патша була белү. *Патшалык — гаскәр белән, гаскәр — мал белән, мал — рәгыять [ил халкының күндәмлеге] белән, рәгыять — гаделлек белән.* Мәкаль.

2. *к.* самодержавие. *Студент Ульяновның дөрес чыкты сүзе: Патшалыкның ауды черек стенасы.* Ә. Фәйзи.

3. *иск.* Дәүләт.— *Алты патшалыкка бер үзебез каршы торабыз бит, Айтуган бабай, авыррак шул.* Г. Бәширов. *Патшалыклар бетә, яулар үтә, Таулар иңә — Идел югалмый.* Г. Афзал. || Берәр төрле күренеш хөкем сөргән урын. *Суыклар патшалыгы [котып турында].* □ *Ул [Г. Камал] татарның „караңгылык патшалыгы"на каршы сугышучы көчле отрядның алдынгы штык очына әйләнә.* М. Гали.

Патшалык итү — хакимлек итү, башлык булып тору. *Шул рәвешчә яңа „президент" патшалык итә башлады.* Н. Фәттах.

ПАТШАЧЫ *и.* Патшага турылыклы, самодержавие яклы кеше, монархист, карагруһ.

ПАТШАЧЫЛЫК *и. к.* монархия. *Шулай да Курмаши патшачылыкның үзен гомумән социаль төзелеш буларак гаепләүгә, фаш итүгә кадәр күтәрелеп җитә алмаган.* Х. Госман.

ПА'УЗА *и.* Эштә, сөйләүдә һ. б. кыска гына тукталыш, туктап тору. — *Алайса ---, — диде егет, мәгънәле пауза белән, — карап кайтыгыз, матур урыннар...* Ш. Маннур. || Сәнгатьтә — сәхнә әсәрләре куелышында, шулай ук шигырь, доклад һ. б. ны сөйләгәндә билгеле бер эффект тудыру өчен ясала торган кыска тукталыш, тыныш. *Шигырьдә --- ритмик пауза белән синтаксик паузаның ярашмавы да очрый.* Н. Юзиев. *Рифма, ритм, цезура, пауза, музыкалылык мәсьәләләрендә яшь шагыйрь үзенә карата таләпчәнлек күрсәтә.* Г. Кашшаф.

ПА'ФОС *и. кит.* Дәртле рухлану, дәрт, күтәренкелек, энтузиазм. [*Г. Камал*] *әсәрләренең эчтәлеге революцион пафос һәм сыйнфый көрәш мотивлары белән сугарылды.* М. Гали. *Шагыйрьнең янган йөрәгеннән чыккан нәфрәтле сүзләрен Фатыйма мөмкин кадәр көчлерәк пафос белән укырга тырышты.* Г. Әпсәләмов.

ПА'ФОСЛЫ *с. кит.* Дәртле, ялкынлы, күтәренке рухлы. *Кыз егетнең позасын һәм пафослы сүзләрен яратмаганлыкны аңлатырга теләде.* К. Тинчурин. *Бездә кайбер иптәшләр бар, аларның --- шигырьләренең эчләрендә бик күп пафослы сүзләр була.* Һ. Такташ.

ПАЦИЕНТ *и.* Врачка күренергә яки дәваланырга килгән авыру. *Дминәнең беренче пациенты Гарифулла карт булды.* Г. Минский.

ПАЦИФИЗМ *и.* Һәртөрле сугыштан (шул исәптән гадел, революцион сугышлардан һәм милли азатлык сугышларыннан) баш тарту — капиталистик мөнәсәбәтләрне саклап калу яклы буржуаз политика.

ПАЦИФИСТ *и.* Пацифизм тарафдары.

ПАЦИФИСТЛА'РЧА *рәв.* Пацифистларга хас булганча.

ПАЦИФИСТЛЫК *и.* Пацифист булу; пацифистларга хас сыйфатлар яки идеяләр. *М. Гафуриның талантлы иҗаты --- пацифистлык йогынтыларын баштан кичереп --- үсә.* М. Җәлил.

ПАЧАС *и. диал.* Өй мүкләү өчен кулланыла торган җитен чүбеге. *Райпланнан ике йөз килограмм пачас бирергә тиешләр иде.* М. Мәһдиев.

ПА'ЧКА *и.* 1. Беришле предметларның яки беришле массаның бер стандарт төргәге. *Бер пачка бөртекле чәй.* □ *Миңа дуслык ясыйсыгыз килсә, бер пачка тәмәке алыгыз.* Ә. Фәйзи.

2. Балериналар киеме — берләштереп тегелгән каткат кыска юбкалар комплекты. *Мөнирә рояль янына килеп утырды. Киемнәрен салып, балет пачкасы киеп өлгергән.* Г. Әпсәләмов.

ПА'ЧКАЛАП *рәв.* Пачкалар берәмлегенчә; күпләп-күпләп. *Акчаны пачкалап санау (тоту).*

ПА'ЧКАЛАУ *ф.* Пачкалар рәвешенә китереп төрү. *Вакланган чимал тураү станогыннан --- иләк аша үтә һәм пачкалау автоматына озатыла.* Соц. Тат.

ПА'ЧКА-ПА'ЧКА *с.* Бергә торган (салынган) күп пачкалар рәвешендәге. *Герләр, тәлинкәле үлчәүләр, пачка-пачка пакетлар салып, нефть якларына киттек.* Г. Галиев. *Сумкада --- пачка-пачка акчалар белән бергә паспорт --- бар иде.* М. Хәсәнов.

ПАЧТЫР-ПЫЧТЫР *аваз ияр.* Су белән төрле эшләр эшләп (нәрсәне дә булса юып һ. б) йөргәндә чыккан тавышларны белдерә. *Мин җылы юрган астында йоклый рәхәтенә җиңелеп, хатынның пачтыр-пычтыр эшләп йөргәнен тыңлап ятам.* М. Әмир.

ПАША *и.* Элекке Төркиядә, Мисырда һ. б. кайбер илләрдә югары хәрби һәм гражданлык титулы яки шул титулга ия булган кеше. *Төрек пашаларының сәясәтләренә тәгаҗҗеб итмичә [гаҗәпләнмичә] мөмкин түгел.* Шура. *Мостафа Кәмал паша хәрәкәте — шул үк дәрәҗәдә төрек халкының үз хәрәкәте.* Ф. Әмирхан.

ПАШАЛЫК *и.* 1. Паша булу вазифасы; паша дәрәҗәсе, титулы. *Пашалык исемен алса, „яшь төрекләрнең" һәркайсы Габделхәмитнең [солтанның] кулын үбәргә әзер торалар. Инкыйлап алар өчен — җир, дәрәҗә, пашалык.* Ә. Фәйзи.

2. Солтан Төркиясендә паша идарә итә торган өлкә.

ПАШТЕТ *и.* 1. Ботка хәленә җиткереп тарттырылган ит массасы; шундый ит салып пешерелгән бәлеш.

2. Өстенә нинди дә булса җиләк-җимеш изеп ягылган (яки эченә катламлап салынган) камыр ашы. [*Әни*] *чәй янына куелган балан паштеты, бәрәңге пәрәмәче, төче коймак һәм таба күмәче кебек сыйлар арасында сайлана башлады.* М. Әмир.— *Җиләктән пешерелгән паштетым бар, шуны алып кит, булмаса.* Ә. Фәйзи.

ПАЯЗ, ПАЯЦ *и. иск.* Цирк клоуны.— *Әллә син дә кәмиттә паяз булмакчы буласыңмы?* Г. Камал.

ПАҢГЫ *и. диал.* Гөмбә. *Паңгы булдыңмы — кер кызауга.* Мәкаль.

Паңгы баш *туп.* — ахмак, аңгыра. [*Исмәт:*] *Хәзергесе заманда кешенең яхшы аты — кубышка. Паңгы баш булма, аңларга кирәк!* Г. Әпсәләмов.

ПЕБЕТ *и.* Бытбылдыкның бер төре; *русчасы:* перепёлка. *Кара урманнарның уртасында Карчыгалар куа пебетне.* Җыр.

ПЕГАС *и.* Борынгы грек мифологиясендә канатлы ат, дөлдөл, тулпар (поэтик рухлану, илһам мәгънәсендә кулланыла). *Пар пегасым, толпарым син—Нәфрәтем, мәхәббәтем.* Х. Туфан.

ПЕД- Кушма сүзләрдә „педагогик" мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **пединститут, педпрактика, педсовет, педучилище.**

ПЕДАГОГ *и.* Тәрбияләү һәм белем бирү белән шөгыльләнүче кеше, укытучы. *Татар опера кадрларын чын күңелдән сөеп тәрбияләүчеләр Мәскәү консерваториясенең эре белгечләре, профессорлары, педагоглары булдылар.* М. Җәлил. *Бу безнең карт педагогларыбыздан Асия ханым, ялгышмасам, атказанган укытучы.* Ә. Фәйзи. || *күч.* Остаз. *Я, кемнәр соң ул кешелек дөньясының иң бөек педагоглары?* Р. Ишморат.

ПЕДАГО'ГИК *с.* 1. Педагогка хас булган. *Педагогик талант. Педагогик осталык.* □ *— Гөлбану тагын берәр җирдә шундыйрак педагогик хикмәт ташласа, концерт тәэмин ителде дигән сүз.* Ш. Камал. || Педагоглар, укытучылар хәзерли торган. *Хөсәения мәдрәсәсе --- урта педагогик мәктәп булып, яңабаштан төзелә.* Г. Кашшаф.

2. Педагогикага караган, педагогикага бәйләнешле. *Педагогик тикшеренүләр. Педагогик әдәбият.* || Педагогик кагыйдәләргә, таләпләргә туры килә торган. *Педагогик алымнар.* □ *Сак-сок бәетләре берничә йөз еллар буенча халык арасында бала тәрбияләүдә педагогик функцияләр үтәп килде.* Каз. утл.

ПЕДАГО'ГИКА *и.* Тәрбияләү һәм белем бирү турындагы фән. *Совет педагогикасы баштан ук төрле милли мәктәпләр өчен аерым дәреслекләр булдыру политикасын алга сөрә.* Каз. утл. *Кайбер укытучылар --- педагогиканы — тәрбия эшен — Макаренко сүзләрен ешрак телгә алудан гыйбарәт дип аңлыйлар.* А. Тимергалин.

ПЕДАГО'ГИЯ *и.* 1. *иск. к.* педагогика. *Ушинский— педагогия фәненә беренче нигез салучыларның берсе.* Р. Ишморат.

2. Тәрбияләү һәм белем бирү эше, шөгыле яки тәгълиматы, алымнары.— *Болай булгач, егет, синең педагогия юлына китүең вакытлы бер зәвык кына булмаган икән!* Г. Бәширов. || *с. мәгъ.* Шул эшкә, шөгыльгә хәзерли торган. *Педагогия институты.*

ПЕДАГОГЛА'РЧА *рәв.* Педагогларга хас булганча. *Бер төркем укытучы ярсыныш завхозга ташланды: мәсьәләгә педагогларча килү түгел бу.* Г. Ахунов.

ПЕДАГОГЛЫК *и.* Педагог булу. — *Сез педагоглыкны алтынчыдан башлыйсызмы әллә? — дигәнгә Рушад сискәнеп китте.* М. Мәһдиев.

ПЕДАЛЬ *и.* Төрле машиналарда һәм музыкаль инструментларда аяк көче белән берәр механизмны хәрәкәтләндерү яки тотып тору өчен эшләнгән аяк басу урыны; тәбәлдерек. *Гаяз педальне әйләндерүдән туктады да, велосипедны үз иркенә куеп, тауга түбән очып төшә башлады.* И. Гази. *Ящь кенә малай, рояльнең ике педаленә дә басып, колак тондырып уйный.* Ш. Усманов.

ПЕДАНТ *и.* 1. Үз фәненнән башканы белми һәм (үзенең махсус гыйлеменнән чыгып кына) башкаларга акыл өйрәтергә ярата торган галим яки укымышлы.

2. Билгеле бер кагыйдәләрне кирәгеннән артык төгәллек белән үтәргә тырышучы кеше.

ПЕДАНТЛА'РЧА *рәв.* Педантларга (2 мәгъ.) хас булганча. *Немецлар — кагыйдә һәм тәртип, педантларча төгәллек һәм бердәм хәрәкәт ярата торган кешеләр.* Ш. Маннур.

ПЕДАНТЛЫК *и.* Педант булу.

ПЕДИАТР *и.* Балалар врачы, педиатрия белгече.

ПЕДИАТРИ'Я *и.* Бала авырулары һәм балаларны дәвалау турындагы фән. | *с. мәгъ. Соңрак Хәбир аның [Мәдинәнең] педиатрия факультетының икенче курсында укуын белде.* Ш. Хөсәенов.

ПЕДИКЮР *и.* Аяк тырнакларын тазарту, ялтырату һәм сөялләрне кисү. *Педикюр ясату.*

ПЕДИКЮ'РША *и.* Педикюр ясаучы хатын-кыз, педикюр ясаучы оста.

ПЕЗЕ'ТА *и. к.* песета.

ПЕ'ЗО, ПЕ'СО *и.* Латин Америкасы илләрендә акча берәмлеге.

ПЕЙЗАЖ *и.* 1. Билгеле бер урынның, якның гомуми күренеше. *Агыйдел буе пейзажы. Төньяк пейзажы.* □ *Пейзаж тагы да ямьләнә, җанлана төшкән.* Г. Минский.

2. Табигать күренешләре, билгеле бер урын төшерелгән рәсем, картина. *Стеналарга эленгән япон пейзажлары күңелебездәге моңсулыкны бары тирәнәйтәләр генә иде.* А. Шамов. || Табигать күренешләренең тасвирламасы. *„Эшче" поэмасында табигать картиналары — пейзаж юк диярлек.* Г. Нигъмәти. *М. Укмасыйның „Таң", „Кыш", „Яз" кебек пейзаж шигырьләре бар.* И. Нуруллин.

ПЕКА'РНЯ *и.* Икмәк, күмәч һ. б. пешерә торган зур булмаган предприятие (цех һ. б). *Хәлим ат җикте. Ашханәдә эшләүче бер хатын белән пекарнягa барып, чәнә тутырып ипи-күмәч алып кайттым.* Г. Гобәй.

ПЕКИН: пекин үрдәге — ак каурыйлы, эре гәүдәле үрдәк токымы. *Агачлар --- күләгәсендә --- зур түшле пекин үрдәкләре чүпләнеп йөриләр.* Ф. Хөсни.

ПЕЛ *и. сир.* 1. Тоташ зур ит кисәге; казылык.

2. Юан тән әгъзасы, мускул. *Пеленә карама, фигыленә кара.* Мәкаль.

ПЕ'ЛЕНГ *и.* 1. *махс.* Тавыш яки яктылык килгән юнәлеш белән компас угы юнәлеше арасындагы почмак.

2. Махсус аппаратлар белән бик ерактан тыңлана торган тавыш сигналы. *Пеленгатор ярдәмендә пеленг кабул итү.*

ПЕЛЕНГА'ТОР *и. махс.* 1. Пеленгация приборы.

2. Пеленгация белгече — тыңлаучы, аппаратчы һ. б. *Диңгезне тыңлый алу җиңел эш түгел. Хәтта тәҗрибәле пеленгатор да 75—80 пеленг кабул иткәннән соң арый.* Эврика.

ПЕЛЕНГА'ЦИЯ *и.* Пеленгларны тыңлау, „кабул итү" эше.

ПЕЛЛА'ГРА *и. мед.* Азыкта РР витамины җитмәүдән килеп чыга торган тире авыруы.

ПЕЛЛӘНҮ *ф. диал.* 1. Симерү (терлек-туар турында). *Пелләнеп җитү.*

2. Тән әгъзалары юанаеп, кабарып тору, таза булу. *Пелләнмәгән — телләнгән.* Мәкаль.

ПЕЛЛӘҮ *ф. диал.* Суелган терлекне ботарлау — махсус өлешләргә бүлгәләү.— *Симерде ул [сыер], шуңа азына. Актык көне аның бүген. Пеллибез аны иртәгә.* М. Мәһдиев.

ПЕЛТ *аваз ияр.* Кинәт кенә яки көттереп су өстенә тамган тамчы тавышын белдерә. *Самоварда су бетә, тамчы гына тама, пелт-пелт килә.* М. Әмир. || *рәв. мәгъ.* Кинәт ясалган йомшак хәрәкәт турында. *Малай --- онытылып утыра-утыра да башын пелт калкытып куя.* Г. Гобәй. *Лампаның мае бетеп, пелт-пелт итеп, сүнәргә әзерләнә башлады.* М. Галәү.

ПЕЛӘМӘЛЕК *с. гади с.* Токымлы (иркәк терлекләр турында гына). *Пеләмәлек үгезебез, айгырыбыз белән үзебезнең тирәдәге авылларга үрнәк булып торабыз.* Г. Толымбай.

ПЕЛӘШ 1. *с.* Чәче коелып, баш тиресенең бер өлеше яки бөтен башы ялтырап торган (кеше турында). *Үзе яшь кенә булса да, башы пеләш кенә доктор нәрсәдер язып утыра. Безнең алда аның шалканнан такыр пеләш башы гына ялтырый.* М. Әмир.

2. *и.* Баш түбәсендә чәч коелган урын. *Әхмәт --- писарь Егорның пеләшен чеметкәләп алды.* Х. Кәрим.

ПЕЛӘШЛӘНҮ *ф.* Пеләш булып калу. [*Гарәфи абзыйның*] *баш түбәсе пеләшләнгән, чигә чәченә чал кунган.* Г. Әпсәләмов.

ПЕ'МЗА *и.* Көпшәк, күбекле вулканик тау токымы (төзү материалы буларак һәм нәрсәне дә булса ышкып ялтырату өчен файдаланыла). *Әрмәнстан төрле төзү материалларына: туфка, пемзага, базальтка, мраморга, известьташка, гранитка бай.* СССР экон. геогр.

ПЕНАЛ *и.* Каләм, карандаш һ. б. язу әсбаплары салып йөртү өчен озынча кечкенә тартма.

ПЕНА'ЛЬТИ *и.* Футбол уенында капкадан унбер метр ераклыкта торып штраф тубы тибү. *Футбол уйнаганда ул [Илнур] --- каршы як сакчының кулы белән уйнап алуын күргән булса да: „Хәрәмләшмәгез! Пенальти, пенальти!" дип, бугаз ертып акырырга тотынмады.* Э. Касыймов.

ПЕНИЦИЛЛИН *и.* Күгәрек гөмбәчекләренең бер төреннән алына торган дару препараты — антибиотик. *Варисның дикъкатеннән бернәрсә дә читтә калмады. Өстәлгә тезелеп куелган пенициллин, сульфидин, террамицин кебек дарулар да.* М. Хәсәнов.

ПЕНО- Кушма сүзләрдә „күбекләндерелгән" мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **пенобетон, пеносиликат, пенометалл.**

ПЕНОПЛАСТ *и.* Күбекләндерелгән (эчендә тишек һәм куышлыклар күп булган) пластмасса.

ПЕНСИОНЕР *и.* Пенсия алып тора торган кеше. *Персональ пенсионер.* □ *Беренче яшь монтёрлар хәзер инде ихтирамга лаеклы пенсионерлардыр.* Г. Галиев.

ПЕ'НСИЯ *и.* Озак еллар хезмәт иткән өчен яки инвалидлыкка, гариплеккә, картлыкка карап хөкүмәт тарафыннан даими бирелә торган акча. *Гөләндәм әбигә Совет күп итеп пенсия билгеләде.* Г. Гобәй. || *кыек килеш форм.* Пенсия алып яшәү хәле. *Пенсиягә чыгу.* □ *Шушы көннәрдә автотранспорт эшчесе Бану Афзаловна дигән хатынны пенсиягә озатканнар иде.* М. Хәсәнов.

ПЕНСНЕ *и.* Борынның ике күз арасындагы өлешенә пружина ярдәмендә эләктереп куела торган күзлек. *Өстәл янында ак чырайлы, ачыяңаклы, кылыч борынын пенсне белән чеметтергән бер кеше кәгазьләр актарып утыра иде.* И. Гази. *Рәшат, күзендәге ал-*

тын пенснесен алып, аның пыялаларын яулыгы белән сөртә-сөртә, сүзендә дәвам итте. Ф. Әмирхан.

ПЕРГА'МЕНТ *и.* 1. Борынгы заманда язу-сызу өчен махсус эшкәртелгән бозау тиресе. *Пергам шәһәрендә китапларны бозау һәм яшь сарыкларның эшкәртелгән тиреләренә яза башлыйлар. Менә шушы тирене пергамент дип атап йөртәләр.* Робинзон әзл. || Шундый тирегә язылган борынгы язу, ядкарь.

2. Сыекчаларны, юешне үткәрми торган кәгазь. [*Немец*] *пергаментка төргән өч кисәк нәрсә китереп безнекеләр алдына салды.* Ә. Еники.

ПЕРГАМИН *и.* 1. Калька ясауга китә торган юка һәм ныклы кәгазь.

2. Каралты-кура түбәсен ябуда кулланыла торган махсус катыргы.

ПЕРЕВОД *и.* Почта яки банк системасы аркылы җибәрелгән (күчерелгән) акча. *Газеталар, хатлар, переводлар, Посылкалар кайта Акшарга.* Ш. Маннур.

ПЕРЕВОЗ *и. сөйл.* 1. Зур елга аркылы паром яки көймә белән чыгу урыны. *Фәйрүзә, көймәне Услон перевозы юлыннан юнәлтеп, койрыкта утыра.* К. Нәҗми.

2. Паром көймәсе. *Перевоз Казан тамагындагы куе таллыкларга барып туктады.* М. Гали.

ПЕ'РЕКИСЬ *и.* 1. Соң дәрәҗәдә кислород белән туенган окись. *Водород перекисе. Марганец перекисе.*

2. *сөйл.* Чәчне саргайту өчен кулланыла торган водород перекисе. [*Фойеда*] *кына һәм басма, ләпес һәм перекись белән буялган чәчләр.* Ш. Хөсәенов.

ПЕ'РЕПИСЬ *и.* Халык санын алу.— *Перепись вакытында сельсоветтан килеп миннән: сездә ничә ир кеше? — дип сораганнар иде.* Ә. Фәйзи.

ПЕРЕС *ы.* Мәчеләрне куып җибәргәндә әйтелә. *Җалай мәчене: — Кит, мур кыргыгы, перес! — дип куып төшерде.* Г. Толымбай. [*Песи*] *Перес! дисәң — куркып яшел күзен йома; песекәй, дип иркәләп сыйпасаң — ача.* С. Баттал.

ПЕРИГЕ'Й *и.* Ай яки ясалма иярчен орбитасының җиргә иң якын ноктасы.

ПЕРИ'МЕТР *и.* Яссылыктагы геометрик фигураның барлык якларының озынлык суммасы.

ПЕРИ'ОД *и.* 1. Дәвамында берәр нәрсә булып үткән, башкарылган яки тәмамланган вакыт аралыгы, чор, дәвер. *Буржуаз революцияләр периоды. Чәчәк ату периоды.*

2. *мат.* Чиксез унарлы вакланмада кабатланучан цифрлар группасы.

3. *лингв. к.* тезем (4 мәгъ.).

ПЕРИО'ДИК *с.* 1. Билгеле бер шартларда тигез аралык белән кабатлана торган. *Элементларның периодик системасы.*

2. Билгеле бер вакыт берәмлеге үткән саен бер мәртәбә бастырылып чыгарыла торган. *Периодик басма.*

ПЕРИСКОП *и.* Яшеренгән җирдән, су астыннан һ. б. ш. урыннардан тирә-якны күзәтергә мөмкинлек бирә торган оптик прибор. *Муса --- наводканы төгәл ноктаналарга куйды да күзләре белән перескопка ябышып калды.* Ш. Маннур.

ПЕРИТОНИТ *и.* Корсак ярысы ялкынсынуы.

ПЕРИФЕРИ'Я *җый. и.* Илнең яки берәр административ берәмлекнең (өлкәнең һ. б.) үзәгеннән читтә урнашкан җирләр. *Иҗат эшенең торышын тикшерү өчен периферия театрларына үзәктән махсус комиссияләр җибәрелә.* Х. Сәлимҗанов.

ПЕРИФРАЗ *и. к.* Перифраза.

ПЕРИФРА'ЗА *и.* Аерым сүз яки тәгъбир мәгънәсендә кулланылган тасвирлы сүз тезмәсе, мәсәлән: „күсе“ яки „тычкан“ дигән мәгънәдә „идән асты кошы“ дип сөйләү.

ПЕРЛАМУТР *и. к.* сәдәп (2 мәг.). *Диңгез кабырчыгыннан перламутр алу.* || *с. мәгъ.* Шуннан эшләнгән. *Мәйданның бер кырыенда Иргали утыра, кулында — баян. Аның зур бармаклары перламутр төймәләр өстендә гажәп җитез йөгерәләр.* И. Салахов. *Гадәттәгечә, перламутр чәчәкләр белән бизәлгән түгәрәк өстәл янына утырдылар.* К. Нәҗми.

ПЕРЛОН *и.* Синтетик сүснең бер төре; шул сүстән ясалган тукыма. *Чибәркәем төяп кайткан нейлоннар, Әллә нинди силоннар һәм перлоннар.* Ә. Ерикәй.

ПЕРМАНЕНТ *и.* 1. Махсус ысуллар (электр һ. б.) кулланып, чәчне берничә ай буена язылмый, җәелми торган итеп бөдрәләтү. *Перманентның --- зарарын киметер өчен, чәчне юганнан соң берничә көн үткәч бөдрәлиләр.* Көнкүреш...

2. *с. мәгъ.* Озак дәвам итә торган, дәвамлы. *Перманент революция теориясе. Перманент үсеш.*

ПЕРМЬ: пермь чоры, пермь системасы *геол.* — палеозой эрасының бишенче геологик чоры һәм шул чорга караган тау токымнары.

ПЕРПЕНДИКУ'ЛЯР *и.* Башка бер туры сызык яки ясылык белән туры почмак ясап кисешә торган туры сызык. *Ясылыкка перпендикуляр төшерү.* |*с. мәгъ. Узара перпендикуляр сызыклар.* | *хәб. сүз функ. Евклид үзенең геометриясендә: ике параллель бер үк турыга перпендикуляр булырга тиеш, дигән фаразга таяна.* Ж. Тәрҗеманов.

ПЕРРО'Н *и.* Вокзал янына килеп туктаган вагоннарга пассажирлар менеп-төшеп йөрсен өчен ясалган платформа. *Төхфәт, --- вагоннан төшеп, перрон буенда тезелеп торган сатучы хатыннардан --- бер арыш икмәге алды.* Ш. Камал. *Поезд килеп җитте. Хисаметдин, чемоданын перрон асфальтына куеп, балалары белән саубуллашты.* Ш. Хөсәенов.

ПЕРСОЛЬ *и.* Кер юу порошогына өстәмә состав — тапларны бетерү өчен кулланыла.

ПЕРСО'НА *и. кит. иск.* Шәхес, кеше.

Персо́на гра́та — дәүләт тарафыннан расланып, башка бер илгә махсус җибәрелгән кеше. **Персо́на нон гра́та** — илче, вәкил буларак ышанычны аклаган чит ил кешесе.— *Хәзер үк сезне персона нон грата ясаячаклар һәм сезнең дипломатик карьерагыз тәмам булачак!* Ш. Маннур.

ПЕРСОНАЖ *и.* Драма, роман, поэма һ. б. әдәби әсәрләрдә тасвир ителгән образ. *Актер җитми, иң эшлексез роль кала: Пьесада баш персонаж — король кала.* Г. Афзал. *„Печән базары...“ --- поэмасында төп персонаж — Кисекбаш.* И. Нуруллин.

ПЕРСОНАЛ *җый. и.* Берәр предприятие яки учрежденинең профессиональ уртаклык яисә башка билгеләр буенча аерым группа тәшкил иткән хезмәткәрләре, кешеләр составы. *Техник персонал.* □ *Ашханә персоналының мондый составына ышанмаучылар „Дарья“ исемле ашханәдән справка ала алалар.* Г. Гали.

ПЕРСОНАЛЬ *с.* Аерым кешегә карата булган, шәхси. *Персональ кисәтү.*

Персональ пенсионер — гомуми закон буенча түгел, ә хөкүмәт яки оешма һ. б. тарафыннан махсус билгеләнгән пенсия алучы. **Персональ состав** — *к.* персонал.

ПЕРСПЕКТИВ *с.* 1. Перспективага (1 мәгъ.) карый торган. *Перспектив сызыклар.*

2. Алдагы вакыйгаларны, үзгәрешләрне, үсешне исәпкә алып эшләнгән. *Перспектив план.*

ПЕРСПЕКТИ'ВА *и.* 1. Яссы өсйөздә өч үлчәмле пространствоны ераклык арту белән предметларның кечерәеп күренүен исәпкә алып сурәтләү сәнгате. *Перспектива законнары.*

2. Ерактан күренгән табигать күренеше, манзара. *Хәзер дә сезнең күз алдыгыздадыр: яшеллеккә күмелеп*

утырган матур гына авыл, аның аргы ягында ераклларга киткән киң перспектива, сызылып кына күренгән ерактагы урман. Г. Бәширов.

3. *күч.* Алда көтелгән үсеш мөмкинлекләре, киләчәк. *Татар дәүләт опера театры коллективының перспективасы зур.* М. Җәлил. *Семья тормышы бозыла, Габбасның эш перспективасы җимерелү алдына килеп баса.* Г. Нигъмәти. || Киләчәккә карап, булачак шартларны исәпкә алып эш итүчәнлек. *Колхоз җитәкчеләре арасында төрлесе бар. Бер төрлесе алдагы көнгә карап эшли. Перспектива белән эшли.* С. Рафиков.

ПЕРСПЕКТИ'ВАЛЫ *с.* Үсеш яки файдалану мөмкинлекләре зур булган, өметле. *Перспективалы геологик катлам.* || Кешеләр турында: зур талантка, рухи көчкә, белемгә һ. б. ия булган. *Перспективалы җырчы. Перспективалы работник.*

ПЕРСПЕКТИ'ВАЛЫЛЫК *и.* Перспективалы булу хәле яки хасияте.

ПЕРСПЕКТИ'ВАСЫЗ *с.* **1.** Алдагы үсеш мөмкинлекләре аз булган яки бөтенләй булмаган, бетүгә йөз тоткан.

2. Алдагы үсешне, киләчәкне күз алдына китерми торган.— *Фантазиясез, перспективасыз кеше сез, шул кызганыч.* М. Җәлил.

ПЕРСПЕКТИ'ВАСЫЗЛЫК *и.* Перспективасыз булу хәле яки хасияте. *Әгәр халык --- бәхет өчен көрәш дәртеннән һаман да мәхрүм кала бирсә, нәрсә булыр иде? Билгеле инде — һаман шул перспективасызлык, пессимизм.* И. Нуруллин.

ПЕРТУРБА'ЦИЯ *и. астр.* **1.** Күк җисемнәренең үз орбиталарын үзгәртүе. *Кометалар пертурбациясе.*

2. *күч.* Гадәттән тыш хәл, зур үзгәреш. *Тормышында пертурбация кичерү.*

ПЕРФОКА'РТА *и.* Тиешле мәгълүматлар хисап машинасында эшкәртелерлек итеп языла торган махсус кәгазь. *Тикшеренүчеләр поэманың барлык текстын --- перфокартага күчерделәр.* Эврика.

ПЕРФОРА'ТОР *и.* **1.** Тау токымнарын бораулый торган машина. *Перфоратор бурлау белән уйный, --- бурлау әйләнәләр.* Ш. Маннур.

2. Кәгазь, катыргы һ. б. ш. нәрсәләргә тишек тишә торган машина.

ПЕРФОРА'ЦИЯ *и. махс.* **1.** Махсус кораллар белән тишү.

2. Кинолента һ. б. читенә тезеп тишелгән тишекләр.

ПЕРЧА'ТКА *и.* **1.** Һәр бармакка аерым-аерым бармакчасы булган кул киеме. [*Кәримнең*] *кулында нечкә генә йон перчатка иде.* Г. Ибраһимов. *Вәсилә --- сумкасын өстәл өстенә куйды да кара челтәр перчаткаларын сала башлады.* М. Хәсәнов. || Баш бармагы һәм имән бармагы өчен аерым бармакчалары булган бияләй. *Айсылу алдына ап-ак итеп юган йомшак оекбашлар, ике бармаклы солдат перчаткалары өлә.* Г. Бәширов.

2. *спорт.* Боксёрлар кия торган бик калын, массив бияләй.

◇ **Перчатка ташлау** — 1) *иск.* дуэльгә чакыру билгесе итеп берәрсенең аяк астына перчаткаңны салып ыргыту; 2) көрәшкә чакыру, берәрсе яки берәр нәрсә белән ачык көрәшкә чыгу. [*Г. Камал*] *бу тормышка дошман булып кала һәм үзеңең миссиясен ул тормышка перчатка ташлау белән тәмамлый.* М. Гали. **Перчатка кебек алмашыну (алмаштыру)** — гадәттә алмашынмый, үзгәртелми торган нәрсәләр еш кына алмашына башлау (шундый нәрсәне алмаштыру). *Сугыш тирәсендәге авылларда власть перчаткадай алмашынып торды.* Г. Бәширов.

ПЕРЧА'ТКАЛЫ *с.* Перчатка кигән. *Хәсән, --- юка гына перчаткалы кулларын кесәләренә яшереп: „Кыш җитмәс борын мондый салкыннарның кемгә кирәге бар инде?" — дип уйлады.* Ф. Әмирхан. *Кечкенә кеше --- күзлеген салып, ак перчаткалы бармаклары белән сөрткәләде.* Г. Гобәй.

ПЕС (ПЕС-ПЕС): пес итү — сию (балалар телендә).

ПЕСЕ'ТА *и.* Испаниядә акча берәмлеге. [*Перико:*] *Безнең инде алтмыш өч песета акчабыз бар.* А. Әхмәт.

ПЕСИ *и.* **1.** *сөйл. к.* мәче. *Тәүфыйклы песи дә каймак ашый.* Мәкаль. *Бара торгач Песи тычкан тотуын да авырсынды.* М. Гафури. *Күңелсез үзгәрешләргә артык пошынмаган песи тәпие белән гамьсез генә битен юып утыра иде.* Г. Гобәй.

2. Талның йомшак чәчәк бөреләре. *Песи чыгару.*

Песи борчагы (табаны) — *к.* мәче борчагы. *Койма буйларына үскән бәбкә үләннәре, песи борчаклары, карга борыннары арасында чикерткәләрнең сайраулары ишетелә.* С. Рафиков. **Песи борын** — кыска гына төз борын. *Песи борынлы, ак алъяпкычлы җилбәзәк асрау Хәсәнне --- бер бүлмәгә алып керде.* Ф. Әмирхан. **Песи бүрек** — бик йомшак һәм йонлач ак яки аксыл бүрек. *Өстендәге --- бәрхет бишмәте, песи бүреге --- аның [баланың] сөйкемлелеген тулылап тора иде.* Г. Гобәй. **Песи койрыгы** — 1) *к.* җикән; 2) кыяклылар семьялыгыннан үлән үсемлек; *русчасы:* щетинник. **Песи яфрагы (гөле)** — *к.* яран II. *Тәрәзә төпләрендә — песи яфрагы, ак кына гөлләре.* Г. Әпсәләмов. **Песи үләне (бөтнеге, уты)** — *к.* валерьян. *Аның исен песиләр бик яраталар. Шуның өчен валерьян песи үләне дип атала да.* Робинзон әзл. **Песи җамаягы** — кечкенә җамаяк.— *Унбер яшебездән --- өстәл янында ашаудан тыеп, песи җамаягы белән чаршау эченә куйдыгыз.* Т. Гыйззәт.

◇ **Песи булу, песи кебек (шикелле) булу** — бик тыйнакка, тавыш-тынсызга әверелү.— *Монда гайрәт орган малайларың, анда баргач, бөтенләй песи булдылар да калдылар.* Г. Камал. *Мин, серне бирмәскә тырышып, песи шикелле генә тыңлап утырам.* А. Шамов. **Песи учы кадәр (хәтле, чаклы)** — бик кечкенә мәйдан турында. *Австриядәге крестьяннарның җирләре песи учы хәтле генә — бер таяк кукуруз, бер таяк бәрәңге.* А. Таһиров. **Песием генә** — бик тыйнак кына, шым гына. *Хәлфә килеп җиткәндә --- малайлар песием генә булып калалар.* Г. Бәширов.

ПЕСИЛЕ: песиле тал — тал төрчәсе; *русчасы:* верба. *Бу болыннарда песиле тал яки кызыл тал, талчыбык, --- карагач үсемлекләре үсә.* Умартачылык.

ПЕСИЛӘНҮ *ф.* **1.** Юашланып, тынып, тыйнакланып калу. *Песиләнеп утыру. Песиләнеп китү.*

2. Песиләр (2 мәгъ.) чыгару (тал турында). *Яз --- песиләнгән өянке ботаклары арасында сыерчыклар җырлата.* М. Әмир.

ПЕСИНИСА *и. сөйл. ирк.* Ана (теше) песи. *Әллә нигә бер ялгышып күбәләк күренсә дә, песинисабыз сикереп тота.* С. Рафиков.

ПЕСИ-ПЕСИ *рәв.* Тавышсыз; бик юаш, мескен кыяфәттә. *Сиздермичә, песи-песи генә килеп керим әле.* Г. Бәширов.

ПЕСК *аваз ияр.* Нечкә генә тавыш белән пипелдәү, чыелдау авазын белдерә. *Песк-песк итү.*

ПЕСКЕЛДӘҮ *ф.* Песк-песк итү. *Радиоалгычлар эфир белән тоташуга, бүлмә эче морзе әлифбасының пескелдәүләре белән тула.* Ш. Маннур.

ПЕСКӘЙ *и.* Песине иркәләп атау, аңа иркәләп эндәшү сүзе. *Мияу-мияу, пескәем, көрпә мамык өскәең.* Дәрдмәнд. *Мияу, мияу, пескәем! Барчы, зинһар, чоланга. Майны сакла күседән, Оясыннан чыгарма.* М. Җәлил.

ПЕСНӘК *и.* Чыпчыклар отрядыннан зур булмаган чуар кош; *русчасы:* синица. *Якында гына --- бер бактан икенчесенә оча-оча кара якалы яшел күлмәк кигән купшы песнәкләр сызгыра.* Г. Бәширов. *Бакчага*

көзен --- урманнан бер, ике, әллә ничә төрле песнәк килде. Г. Гобәй.

ПЕС-ПЕС *ы.* Песиләрне чакыру сүзе. [*Шәмси:*] *Күмәчләрен инде калдырып китсәм, песи-мазар тияр микән, рәхмәт төшкере? Пес-пес, пес-пес!.. --- Песие югын юк, ахры.* М. Фәйзи.

ПЕССИМИЗМ *и.* Өметсезлек, киләчәктән тик начарлыклар гына көтү; төшенкелек, дәртсезлек; *киресе:* оптимизм. *Баязитның соңгы заманда гадәттән тыш өметсезлеккә, пессимизмга чумуы билгеле иде.* Г. Ибраһимов. *Әбелмәнихтә пессимизм һәм дөньядан бизү идеясе бик көчле; дөрес, оптимистик мотивлар да юк түгел.* М. Гайнуллин.

ПЕССИМИСТ *и.* Пессимизмга бирелгән кеше. *Башта ук шуны әйтим: без пессимист булабыз; дөнья сүгәбез, хәятта ямь юк, кызык юк дибез,— бар да юләрлек, бар да сукырлык.* Г. Ибраһимов. | *с. мәгъ.—Мин андый пессимист кешеләрне яратмыйм.* А. Әхмәт.

ПЕССИМИ|СТИК *с.* Пессимизмга караган; пессимизм белән сугарылган. *Тукайның изҗаты һич тә тулаем пессимистик рухта түгел.* И. Нуруллин. *Татар буржуазиясе яклаган музыка баштан ахырына хәтле „милли" һәм үтә чыккан пессимистик музыка иде.* М. Җәлил.

ПЕССИМИСТЛА|РЧА *рәв.* Пессимистларга хас булганча, төшенке рухлы. *Дөньяга пессимистларча карау.*

ПЕССИМИСТЛЫК *и.* Пессимист булу хәле. *Пессимистлыкка бирелү. Әсәрдә пессимистлык мотивлары.*

ПЕСТӘ *и.* Җылы якларда үсә торган каурый сыман яфраклы агач; *русчасы:* фисташка. *Пестә яфрагы.* □ *Урта Азиядә --- урманнарда миндаль, пестә һәм җимеш бирә торган бик күп кыргый агачлар да үсә.* Робинзон әзл. || Шул агачның яшькелт яки коңгыртяшел төстәге чикләвеге. *Пестә чикләвеге.*

Пестә борын — кечкенә озынча борын. *Кыз сылу, йөзе нурлы, матур, пестә борынлы.* Н. Арсланов.

ПЕТА|РДА *и.* Дары тутырылган металл савыттан гыйбарәт кулдан эшләнгән примитив снаряд яки бомба. *Бер студент --- атлы полициягә петарда ыргыта. Ясалма бомба шартлый, ләкин ул беркемгә дә зыян китерми.* А. Расих.

ПЕТИТ *и.* Басма шрифтның вак төрләреннән берсе.

ПЕТИ|ЦИЯ *и.* Хөкүмәткә яки урындагы властьларга язма формада тапшырылган коллектив үтенеч. *Без дә, мәсьәләне бик әтрафлы [һәр яктан] тикшереп, петиция яздык.* А. Расих.

ПЕТЛИ|ЦА *и.* Хәрби һ. б. форма киеменең якасына дәрәҗәне, чинны аеру билгесе итеп тегелгән тукыма кисәге, төсле тасма.

ПЕТРОГРА|ФИЯ *и.* Тау токымнарының физик һәм химик үзлекләрен өйрәнә торган фән—геологиянең бер тармагы.

ПЕТРУ|ШКА *и.* Зонтиклылар семьялыгыннан яфраклары һәм тамыры аш тәмләткеч сыйфатында кулланыла торган ак кишер сыман яшелчә. *Пешкән бәрәңгегә туралган петрушка яфраклары сипсәң, нинди тәмле була.* Робинзон әзл.

ПЕТУ|НИЯ *и.* Хуш исле, кыңгырау сыман чәчәкләре төрле төстә була торган декоратив үлән үсемлек.

ПЕХО|ТА *и.* Җәяүле гаскәр. *Яйсан стансасы --- башкорт пехотасы тарафыннан саклана иде.* Ш. Усманов. *Алдан кавалерия, аннары, саф-саф тезелеп, пехота, аннары тупка җигелгән атлар әкрен генә басу капкасыннан чыга башлады.* И. Гази.

ПЕХО|ТАЧЫ *и.* Пехотада хезмәт итүче солдат (гаскәри). [*Разведчиклар*] *алгы кырыйда пехотачыларның траншеяларыннан финнар ягына карап тордылар.* Г. Әпсәләмов.

ПЕЧАТЬ *и.* **1.** Берәр өсйөзгә (кәгазьгә, сургучка һ. б.) билгеле бер язуны, номерны яки рәсемне һ. б. басу өчен кулланыла торган махсус әсбап. *Өстәлдә бер печать, дүрт штемпель.* М. Җәлил. *Айсылу алдына әллә ничә печать, әллә никадәр ачкыч китереп салдылар.* Г. Бәширов.

2. Шундый прибор белән документка басылган әз, тамга, таныклык билгесе, мөһер. *Хәлил зур печать басылган кәгазьне кат-кат укыды.* К. Тинчурин. || Берәр товарны, продуктны чыгарган предприятиенең шул товарга яки аның тышлыгына һ. б. басылган билгесе; этикетка. *Эйфель манарасы башына менүчеләргә Эйфель манарасы печатена төрелгән конфетлар, шоколадлар саталар.* Г. Гали. *Печатена биш йолдыз сурәте төшкән сары бутылканы ача иде ул.* М. Әмир.

3. *күч.* Начар исем, кушамат, ләкаб турында. *Ләгънәт печате басу.* □ [*Кәримгә*] *„лодырь" дигән печать тактылар да Дүрт ягын да кыйбла иттеләр.* М. Җәлил. *Шул почмакка һәр көн Печән базары мещаннары җыелыша һәм узган-барганга көфер печате сугып --- калалар иде.* М. Гали.

ПЕЧАТЬЛЕ *с.* Печать (2 мәгъ.) төшерелгән, басылган. *Әлеге кеше --- печатьле, штамплы соры кәгазьне язу өстәле тартмасына салып куйды.* Ш. Камал. *Минем кулыма печатьле зур язу китереп тоттырдылар.* М. Гали.

ПЕЧАТЬЛӘҮ *ф.* **1.** Печать (1 мәгъ.) басу (сугу). *Документны печатьләү.* □ *Өлгерде бу [хат]. Печатьлисе генә бар.* М. Җәлил.

2. Пломба салып бикләү, сургучлау. *Ротный командир белән берничә офицер солдатларның урыннарын тентеп, сандыкларын печатьләп, аерым бүлмәгә тутыра башладылар.* М. Гафури. || Озакка бикләү. *Патша [староверларның] илле елдан бирле печатьләнеп яткан чиркәүләрен ачарга рөхсәт бирде.* Ш. Мөхәммәдев.

3. *күч. сөйл.* Тәмамлау, төгәлләү. *Камилә --- быел өченче курсны печатьләп бетереп чыга ала.* М. Әмир.

ПЕЧЕНЕГ *и. к.* бажанак.

ПЕЧЕ|НЬЕ *и.* Татлы камыр кисәкләреннән пешерелгән кондитер ашамлыгы. *Печенье сортлары.* □ *— Миндә бик йомшак, бик тәмле печенье бар. [Оныгым] кимерер.* Э. Касыймов.

ПЕЧТЕК, ПЕЧТИК *с. диал.* Бик аз, аз гына. [*Йосыф:*] *Әти, анда печтек кенә түгел, шактый зур ремонты бар тракторның.* Ә. Фәйзи.— *Печтик кенә дә акыл юк бит синдә.* Р. Ишморат. | *рәв. мәгъ. Хәким, тәвәккәлләп:—Печтик кенә әчсәк тә ярый,—диде.* Ә. Еники.

ПЕЧӘН *и.* **1.** Мал-туарга азыкка дип чабылган яки чабып киптерелгән үлән. *Печән кибәне. Печән чабу. Печән җыю.* □ *Әле иртә белән генә кояш нурларына каршы нәфис чәчәкләрен тибрәндереп утырган яшел үлән хәзер печән булып аяк астында ята.* Г. Бәширов.

2. *күч.* Печән чабу эше. *Печәнгә төшү. Печән өсте.* □ *— Әле Хәнәфи туганга әйттем, печәнгә кешене күбрәк җибәр, дидем.* Г. Әпсәләмов. *Озакламый печән өлгерә, кешеләрнең күп өлеше печәндә булачак.* Ш. Камал.

ПЕЧӘНЛЕК *и.* **1.** Печән итеп әзерләрлек әйбәт үлән үсә торган болын, тугай яки алан.— *Быел фермаларда малны ишәйтәбез, терлек азыгы бик күп кирәк булачак! — дип, [Тимери агай] печәнлекне --- артыграк алган иде.* Г. Бәширов. *Гомәр --- кайда нинди чокыр, нинди куаклык, печәнлек барлыгын бик ачык хәтеренә төшерде.* Ә. Еники.

2. Абзарда яки лапаста печәнне тутырып саклау өчен ясалган урын, тезмә. *Ата казлар каңгылдый, печәнлекләрдә бөтен авылны шаулатып тавыклар кытаклый.* Г. Бәширов. *Сәфәргали --- тезмәгә, печәнлеккә менеп, коры печән өстенә йөзе белән капланды да, әнисен сагынып, тавышсыз гына елап җибәрде.* Ф. Хөсни.

ПЕЧӘНЧЕ *и.* Печән чабу, җыю һәм өю эшләрендә эшләүче, печән хәзерләүче кеше. *Бүгеннән соң печәнчеләрне тугайга төшерергә кирәк.* М. Фәйзи. *Каплап алган яшел болын өстен Печәнчеләр арбяк үзәндә.* Ш. Мөдәррис.

ПЕЧҮ *ф.* **1.** *иск. диал.* Тоташ тукымадан (күннән) кием кисү. *Кием печү.* □ *Киемчегә рөхсәт бетәр Тар чалбарлар печәргә.* М. Укмасый.

2. Хайваннарны кастрацияләү — иркәк хайванның күкәйләрен кисеп алу яки орлык каналын өзү (бәйләү). *Иртә белән печкән үгез бозауны районга алып барып тапшырган идем.* Ә. Айдар.

3. *күч. гади с.* Артык кыскарту. *Шулай кырык җәфа чигеп язылган материалны да секретариатта печеп калалар.* А. Гыйләҗев. || Кемне дә булса бик каты алдау, аңарга бик зур зыян салу. *Саттың да эчтең, саттың да эчтең, Кешене түгел, үзеңне печтең.* Д. Гобәйди.

ПЕШЕ *с.* Сыгылмалы һәм нык. *Пеше каеш.* □ *Чыбыкны пеше чакта бөгәләр.* Мәкаль.

ПЕШЕГҮ *ф.* Җылы киемнән яки эссе пар тәэсиреннән тән тиресе кызарып бозылу.— *Бабай, нигә бу туыңны салмыйсың? Яз җитте бит инде, яз! Пешегеп үләрсең.* А. Шамов.

ПЕШЕК *и. диал.* Эсседән чыккан чәер. *Ак чыршының төптән юнылган ботак урыннарыннан тамчы-тамчы булып сары бал төсле пешек сытылып чыккан.* Н. Фәттах.

ПЕШЕКЛӘҮ *ф.* **1.** Агач әйберләрне, себеркене һ. б., сыгылмалырак итәр өчен, кайнар суда яки пар да тотып жебетү. *Парда пешекләнгән яшь тал белән ялан тәнгә --- чаж-чаж сугалар.* М. Гали. || Дезинфекцияләү һ. б. максатлар өчен кайнар су белән чайкау. *Рәүфә чүлмәкләрне шау кайнар су белән пешекләргә тотынды.* А. Шамов.

2. Йомшарту, пешерү өчен кайнар суга салу; парлау. *Гөмбә пешекләү.* □ *Җиренә җиткереп пешекләнгән, парлары чыгып торган башакны ат комсызланып ашады.* Г. Гобәй.

ПЕШЕКТЕРҮ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* пешегү.

2. *к.* пешекләү (1 мәгъ.). *Приказда --- „крестьяннарны җыеп суктырырга пешектерелгән чыбыклар хәзерлә“ диелгән.* Х. Кәрим.

ПЕШЕКЧЕ *и.* Аш-су хәзерләү белән шөгыльләнүче кеше, повар. *Туган апаң оста пешекче булганда, табының мул хәзерләнгәндә, һәркем --- мондый [мактау] сүзләрне ишетә алачак.* Ш. Хөсәенов. | *с. мәгъ. Шаһитләрдән пешекче карчык Миңзифа әбине чакыртып керттеләр.* Г. Ибраһимов.

ПЕШЕКЧЕЛЕК *и.* Пешекче һөнәре, пешекче булу, пешекче шөгыле. *Пешекчелек белән шөгыльләнү.*

ПЕШЕРЕНҮ *ф.* Төрле ашамлыклар пешерү белән мәшгуль булу. *Өйдә шау-шу, көлеш. Пешеренәләр, әзерлиләр, юалар.* М. Җәлил. *Әхмәдинең килене аш өендә пешеренә икән.* А. Таһиров.

ПЕШЕРЕНҮ-ТӨШЕРЕНҮ *ф.* Аш-су, табын хәзерләү белән бик кызу рәвештә мәшгуль булу. *Хәллерәк йортларда кунак алу, бал эчетү, пешеренү-төшеренү кайгысына керештеләр.* М. Гали.

ПЕШЕРҮ *ф.* **1.** Азык-төлек әйберләренең кайбер төрләрен (мәсәлән, камырны) ут өстендә (гомумән, югары температурада) тотып, нинди дә булса ашамлык хәзерләү. *Аш пешерү. Ипи пешерү. Йомырка пешерү.* □ *Миңсылу чынлап та тәмле пәрәмәчләр пешергән иде.* Ш. Камал. *Без ятабыз дымлы землянкада, Бәрәңгене көлдә пешереп.* Ә. Ерикәй.

2. Кайнар температура белән тәэсир итеп авырттыру, җәрәхәтләү (мәсәлән, тән тиресен). *Кулны кайнар суда пешерү.* □ *Миңнулла иреннәрен пешерә башлаган тәмәке төпчеген атып бәрде.* И. Гази. || *күч.* Берәр нәрсә белән тәнгә сугып, ут белән тәэсир иткән шикелле авырттыру. *Җиргә ауган чагында Шәмсинең сул балтырын нидер [пуля] үзәгенә үткәреп пешереп алды.* Г. Бәширов. *Уңлы-суллы бәрелгән кайнар куллар аның [Камалиның] яңакларын пешерделәр.* К. Нәҗми.

3. Кыздыру, яндыру. *Кояш иртәдән алып рәхимсез пешерә.* Ш. Усманов.

4. Кайнатып эшкәртелә торган берәр продуктны, фабрикатны һ. б. эзерләү.— *Мин кирпеч суга алам, мин сабын пешерермен.* Ф. Бурнаш.

5. *к.* пешекләү. *Мунчага барып, каен себеркесен пешерә-пешерә чабыну, юыну, өйдәге аш-чәй — һәммәсе күңеленә рәхәт ятты аның [Хановның].* С. Рафиков.

6. *күч.* Сугышта җиңеп кирәген бирү, тәпәләү, кыйнау.— *Минем буржуйларны пешерәсем килә әле.* М. Фәйзи. *Эх, пешердек Японны без Хасан күле буенда.* Ә. Ерикәй. || Камчылау, чыбыркылау. *Хөснулла, тимеркүк атын нык кына пешереп, Каюмны артта калдырып китте.* Ш. Камал. || Бик каты тиргәү, тәнкыйтьләү. *Шуннан зәһәр хатынның ачуы чыгып, ирен пешерергә керешә.* Т. Гыйззәт. *Офицерлар аны, бөтереп алып, Пешерделәр бик нык үзара. Бер агара егет, бер кызара.* Ш. Маннур.

7. *күч. сир.* Җиренә җиткерү, тәмамлау, төгәлләү. — *Эшне шулай итеп бик ныгытып, пешереп эшләргә кирәк.* Г. Камал.

◇ **Пешереп куйган ди сиңа** *ирон.*— бөтенесен әзерләп, кирәкле шартлар тудырып куелмаган булу турында. *Безнең тау, безнең күл дә аңа „Пешереп куйган“ диеп белә ул [немец].* М. Җәлил.

ПЕ'ШКА *и.* **1.** Шахмат уенында иң түбән дәрәҗәле фигура, җәяүле. *Пешканы ферзьгә чыгару.* □ *Вәли еш кына, пешкаларны кузгатмадымы икән дип, шахмат тактасына һәм Раузага карый, бармак селкеп куя.* А. Алиш.

2. *күч.* Уртача гына сәләтле, башкалар теләгенә буйсынып эш итүчән яки әһәмиятсез шәхес турында. *Пулеметчы өч сугышчы пешка түгел ул, зур көч.* Г. Бәширов.

ПЕШКӘК *и.* **1.** Гөбедә май атлый торган корал — таяк башына беркетелгән тишекле түгәрәк такта кисәгеннән гыйбарәт. *Кымызга пешкәк кирәк, ишәккә күсәк кирәк.* Мәкаль. || Гомумән һәрбер шуның кебек деталь, поршень. *Су басымы астында пешкәк-бөке һаман аска төшеп, цемент катып өлгергәнче, аны труба арты куышлыгына куа.* Нефть тур. хик.

2. Карга тирән батмасын өчен, чаңгы таягына беркетелә торган агач бөжра. *Пешкәк бөгү (ясау).*

ПЕШКӘКЛӘҮ *ф.* Пешкәк белән атлау, язу, туглау. *Гөбедә каймак пешкәкләү.* □ *Ул көне буе диярлек эштә: бия сава, кымыз пешкәкли, самовар кайната.* Каз. утл.

ПЕШТЕЛЕ *и. иск.* Каравылчылы уеннарның бер төре. *Каравылчы --- берәүне дә тота алмыйча, чабаталарын алдырып бетерсә, аңа җәза бирелә: „Пештеле, кабыргага төштеле... һап!“* [*дип сугыла*]. Н. Исәнбәт.

ПЕШҮ I *ф.* **1.** Пешерелгән хәлгә килү, утта торып чилек халәтен югалту. *Без торганда Гөлбикәнең самовары кайнаган, коймагы пешкән иде.* Г. Ибраһимов. *Ул арада Мәүлиханың боткасы да пеште.* Г. Бәширов. *Кәли инде пешеп өлгергән бәрәңгене учактан алып җиргә куйды.* Г. Гобәй. || Кайнап чыгу яки кайнар хәлдә торып, билгеле бер тәм алу (кофе яки чәй турында).— *Я, карчык, чәең пештеме?* А. Әхмәт.

2. Пешекләнү.— *Башакны --- [атларга] пешкән салам белән яхшы иттереп болгатып бирәсең.* Г. Бәширов.

3. Югары температура тәэсиреннән авырту, җәрәхәтләнү (тән, тире һ. б. турында). *Аның [Газинурның] өсте манма су, куллары пешеп, куыкланып беткән.* Г. Әпсәләмов.— *Ашка якын бара күрмә — пешәрсең.* Г. Гобәй.

4. *күч.* Кояш нуры яки ялкын кызулыгы, җил һ. б. тәэсиреннән кызару яки каралу. *Якуб кояшта пешкән муенын, колакларын су астына куеп, күбекне юдырып төшерде.* И. Гази.

5. Тырышып эшләүдән, оялудан кызару, кызарып китү. [*Мәдинә*] *хәзер тирләгән, пешкән хәлдә көлтә бәйли.* Ш. Камал. *Арыган, --- кызарып пешкән кызларыбыз тирән итеп бер суладылар.* Ә. Еники. || Эсседән, кызулыктан яки тирләүдән интегү. [*Мәрьям:*] *Җилән киеп йөргәнгә карап, кешеләр пешеп үлгәннәр иде ди.* Ф. Әмирхан.

6. Өлгерү, җитлегү (җиләк-җимешләр, шулай ук башаклы игеннәр турында). *Бервакыт пешә игеннәр, безгә эш вакыты җитә.* М. Гафури. *Помидорлар пешеп кызарды һәм җиргә иелде.* М. Җәлил. *Миләш пешмәгән иде әле, яңа кызарып килә иде.* Г. Гобәй.

7. *күч.* Барып чыгу, җайлану, рәтләнү.— *Кара әле, --- Сафаның хатыны Бәдрия белән серләрең пешә бугай синең.* Г. Ибраһимов.— *Шаулама, иптәш, эш пеште.* Г. Камал.

8. *күч.* Билгеле бер яктан җитлегү, тәжрибә-белем алу, чыныгу, үсеп җитү. *Карлыгач сахраның матуры булып пешеп өлгерде.* Г. Ибраһимов. *Эштә пештек, эштә гөрләп үстек.* Ә. Ерикәй.

9. *с. мәгъ.* **пешмәгән.** Булдыксыз, юньсез.— *Тагын әйтәм,— диде Гафият,— без үзебез пешмәгән.* И. Гази. — *Ахмак! Җебегән! — ди-ди ярсынып йодрык төйде Госман.— Тәбәнәк кенә, пүчтәк кенә киртәне дә атлап үтә белмә, пешмәгән җан.* Э. Касыймов. || Җитәрлек дәрәҗәдә эшкәртелмәгән, эшләнеп җитмәгән. *Җыентыкка кергән җырларның бик күбесе — чын мәгънәсе белән пешмәгән җырлар.* М. Җәлил. *Бу әсәр һич мәгънәсез эшләнгән, пешмәгән.* З. Мансур.

◇ **Пешкән шалкан** — булдыксыз, юньсез кеше. *Балаң булса, ут булсын, Выжлап очар ук булсын; Җебегән авыз, пешкән шалкан Бар булганчы юк булсын.* З. Бәшири.

ПЕШҮ II *ф. диал.* Туглау, шапыру, атлау. *Май пешү. Бал пешү.* □ *Кырыс җиңги кымыз пешәр; әрле җиңги әйрән пешәр.* Мәкаль.

ПИ I *и. мат.* Әйләнә озынлыгының үз диаметрына чагыштырмасы.

пи саны *мат.*— әйләнә озынлыгының үз диаметрына чагыштырмасын күрсәтә торган сан (ул 3,14 кә тигез).

ПИ II *и.* Фарсы әлифбасында өченче хәреф („п"ның) исеме. *Мин кызлар белән бергә „әлеп, пи, ти, си, җомыкый"ны, бер дә тарланмыйча, кычкырып укый башладым.* Г. Тукай.

ПИАНИ'НО *и.* Кыллары астан өскә таба тартылган, клавишлы музыка коралы; фортепьяноның ян якларына яткырып куелган озынча әрҗә рәвешле бер төре. *Бер кыз, башын арткарак ташлап, кулларын чөеп-чөеп, пианинода уйнап утыра иде.* И. Гази. *Салих Сәйдәшев пианино янына килеп утыра һәм моңа кадәр ишетелмәгән моңлы бер көй уйный башлый.* Х. Сәлимҗанов.

ПИАНИ'ССИМО *муз.* 1. *рәв.* Бик тын, басынкы, пианодан (1 мәгъ.) басынкырак тавыш белән (музыкаль әсәрне башкару турында).

2. *и.* Музыкаль әсәрнең шулай бик тын, басынкы уйнала торган өлеше; бик тын, басынкы уйнау.

ПИАНИСТ *и.* Фортепьянода уйнаучы музыкант. *Безнең совет пианистлары Генрих Нейгауз, Святослав Рихтер --- үзләренең башкаручылык осталыклары белән бөтен дөньяда алдынгылар сафында торалар.* Ж. Фәйзи. [*Мансурның*] *бармаклары скрипач һәм пианист бармаклары кебек җитез һәм сизгер.* Г. Әпсәләмов.

ПИАНИСТЛЫК *и.* Пианист булу.

ПИА'НО *муз.* 1. *рәв.* Тын, басынкы (музыкаль әсәрне башкару турында).

2. *и.* Музыкаль әсәрнең тын, басынкы уйнала торган өлеше; музыкаль әсәрнең тын, басынкы рәвештә уйналышы.

ПИАНО'ЛА *и.* Пианисттан башка уйнату өчен рояльгә яки пианинога куелган пневмо-механик җайланма; шундый җайланмасы булган рояль яки пианино.

ПИАСТР *и.* Төркия, Мисыр һәм кайбер башка илләрдә (ә элегрәк Испаниядә, Португалиядә, Латин Америкасында) вак акча берәмлеге. *Бу семья көнгә тугыз пиастр түләү исәбеннән крестьяннарны эшкә яллый.* Соц. Тат. [*Туристлар*], *унбиш пиастр түләп, бозлы җимеш суы эчтеләр.* С. Сөләйманова.

ПИБЕК *и. диал. к.* тәкәрлек (1 мәгъ.). *Агыйделнең арьягында кычкыралар пибекләр.* Г. Тукай.

ПИБЕП *и. диал.* Чеби, чебеш. *Бардым урманнарга, кичкә калдым, И алмалым, Карчыгалар куа пибепне.* Җыр.

ПИГАМБӘР *и. сөйл. к.* пәйгамбәр. *Мөхәммәт пигамбәргә килгән аятьләрне һәм аның хәдисләрен генә түгел, бәлки бөтен 28 пигамбәргә әйткән аятьләрне аңлатсаң да,* [*алпавытлар*] *сыйныфыннан үз файдаларын оныттыру мөмкин булмаячак.* Урал.— *Оят пәрдәләрегезне йөзегездән ташлап, --- пигамбәрләребезнең шәфәгатеннән мәхрүм калырга сезне нәрсә мәҗбүр итте?* — [*ди мулла*]. Т. Гыйззәт.

ПИГАМБӘРЛЕК *и. сөйл. к.* пәйгамбәрлек. *Укымак— үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр — истикъбальләр тугрысында пигамбәрлек итмәк.* Г. Тукай.

ПИГАМБӘРЛӘНҮ *ф. сөйл. к.* пәйгамбәрлек итү. *Мин пигамбәр түгел. Дмма шәм янында күп әйләнгән күбәләкнең канаты көячәкне алдан хәбәр бирәмен. Болай итүем илә мине „пигамбәрләнә" дип сүкмәгез.* Г. Тукай.

ПИГМЕЙ *и.* 1. Үзәк Африкада яшәүче тәбәнәк буйлы кешеләр кабиләсе һәм шул кабиләнең бер вәкиле.

2. *кит.* Тәбәнәк буйлы кеше.

ПИГМЕНТ *и.* Тере организмда тукымаларга (чәчкә, тәнгә, күзләргә) бирәр төс бирә торган табигый буяу. *Бу — „ярым эшләнгән витамин", үсемлекләрне кызгылт-сары төскә кертә торган каротин пигменты, икенче төрле әйткәндә, билгеле бер төс бирә торган буяу.* А. Расих.

ПИГМЕНТА'ЦИЯ *и. биол.* Пигмент тәэсирендә тере организм тукымалары билгеле бер төскә керү (мәсәлән, язын биткә сипкел чыгу).

ПИГМЕНТЛАНУ *ф. биол. к.* пигментация.

ПИДЖАК *и.* Алдан төймәләнә торган, ачык кайтарма якалы куртка (ирләр костюмы). [*Хәлил*] *итәкләре чигелгән күк сатин күлмәк өстеннән төймәләми генә* [*гадирәк*] *пиджак кигән.* М. Фәйзи.

ПИДЖАКЛЫК *с.* Пиджак тегәргә яраклы; пиджак тегәргә җитәрлек. || *и. мәгъ.* Пиджак тегәргә яраклы материал.

ПИЖА'МА *и.* Өйдә, больницада яки урынга ятканда кияр өчен җиңел тукымадан тегелгән куртка һәм чалбар. [*Аның әтисе*] *өстендә буй-буй сызыклы пижама гына, әле йокысы да ачылып җитмәгән.* Г. Ахунов.

ПИЖА'МАЛЫК *с.* Пижама тегәргә яраклы; пижамага җитәрлек. || *и. мәгъ.* Пижама тегәргә яраклы тукыма.

ПИЖОН *и. сөйл.* Иң соңгы мода белән киенүче һәм үз тышкы кыяфәте белән генә кызыксынучы фырт егет. *Берәү дә үзенең карап үстергән кызын әтисе*

акчасына ялтырап йөри торган, үзенең кулыннан нинди дә булса эш килмәгән шома пижон кулына ансат кына тоттырып җибәрмәс. Ф. Хөсни.

ПИЖОНЛЫК *и.* Пижон булу. *Аның черек пижонлыгы, хатын-кызга шундый түбән карашы беркемгә мәгълүм түгел.* Э. Касыймов.

ПИЗЕЛ *и. диал. к.* миләш. *Күршеләрнең ишегалларында пизел үсә. Аның кызыл тәлгәшләре кояшта ялтырый.* Г. Әпсәләмов.

ПИК *и.* **1.** Очлы башлы биек тау түбәсе. *Ленин пигы. Җиңү пигы.*

2. *махс.* Берәр эш-шөгыльдә, хәрәкәттә кыска вакытлы кискен, кинәт күтәрелеш.

◇ **Пик сәгат(ьләр)е** — транспорт, электростанция һ. б. ш. эш-хәрәкәтендә иң киеренке, тыгыз вакыт. *Кичке пик сәгате — халыкның эштән кайткан чагы, машиналарның күп булуы бер дә гаҗәп түгел.* М. Маликова.

ПИКАДОР *и.* Үгезләр сугышы вакытында үгезне сөңге кадап котырта торган җайдак.

ПИКАП *и.* Йөк яки пассажирлар ташый торган, гадәттә кечкенә ачык автомобиль.

ПИКЕ[1] I *и.* Уң ягына кабарынкы рәсем төшерелгән киже-мамык яки ясалма ефәк тукыма. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Пике күлмәк.*

ПИКЕ[1] II *и. авиа.* Бик зур тизлектә аска таба кадалып очыш (самолет турында). *Алдан килгән өч самолет, пикега кереп (түбәнәеп), юллар өстенә авыр бомбаларын бер-бер артлы төшереп тә җибәрделәр.* Ә. Еники.

ПИКЕТ I *и.* **1.** Берничә кешедән торган сакчы отряд. *Атлы пикет.* || Шул отряд урнашкан урын. *Пикетта тору.* □ *Пикет янына кичләрен солдатлар җыела торган иде.* Каз. утл.

2. Капиталистик илләрдә эш ташлаган эшчеләрнең штрейкбрехерларны предприятиегә кертмәс өчен куелган бер төркеме; шулай ук демонстрацияне төрле һөҗүмнәрдән саклау өчен куелган бер төркем сакчылар. *Нургали агай, Андрей белән киңәшлашеп, завод пристане тирәсенә үз кешеләрдән пикет куюны кирәк тапты.* Г. Минский.

ПИКЕТ II *и.* **1.** *махс.* Җир өстендәге бер ноктадан билгеле бер ераклыкта торган һәм шул урынның югарылыгын билгеләгәндә кагылган казык-нокта. || Җир өстенең югарылыгын билгеләгәндә, шулай ук киләсе эшләр өчен кагып калдырылган номерлы казык.

2. *махс.* Тимер юлның озынлыгын үлчәү берәмлеге (СССРда ул 100 *м* га тигез).

ПИКЕТАЖ *и.* **1.** *махс.* Җир өстен нивелирлаганда билгеле бер югарылыктагы ноктапар сайлау һәм шул урыннарга казыклар кагып чыгу.

2. *с. мәгъ.* Пикетаж белән бәйле. *Пикетаж эшләре.* □ [*Идрис*] *пикетаж дәфтәренең эченнән ике бит кәгазь алып Уразгөлгә сузды.* Ә. Айдар. || Пикетажда күлланыла торган. *Пикетаж баганасы.*

ПИКЕТЛАУ *ф.* Штрейкбрехерларны предприятиегә кертмәү өчен капка янын саклау.

ПИКЕТЧЫ *и.* Пикетта (I) катнашучы кеше. *Маёвканың кайсы урында уздырылачагын аныклап, юлда очрарга тиешле пикетчылар хәбәр итәчәк.* А. Расих.

ПИ'КИ *и.* Кара төстәге сөңге очы рәвешендә ясалган тамгалы уен картасы; карга (4 мәгъ.). *Пики дамасы.* □ [*Бәкер:*] *Юләр, простой белән козырьны ябалармыни?* [*Әхтәм:*] *Козырь пикимени?* [*Бәкер:*] *Пики шул.* Г. Коләхметов.

ПИКИРО'ВЩИК *и.* Пикега кереп (түбәнгә таба кадалып) бомба ыргыта торган самолет.

ПИКНИК *и.* Кырда, урманда, гомумән ачык һавада бергәләшеп ашап-эчеп, күңел ачып ял итү (берничә кеше яки зур төркем турында). *Сакмар буена пикникка чыктык.* З. Бәширн. *Дүшәмбе көн булганга, пароходта пикникка чыгучылар аз иде.* А. Расих.

ПИКНИКЧЫ *и.* Пикникта катнашучы кеше. *Пикникчылар күл буендагы киң карама астына урнашканнар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ПИКНО'МЕТР *и.* Кечкенә күләмле каты җисемнәрнең һәм сыеклыкларның чагыштырма авырлыгын үлчи торган прибор.

ПИКРИН: пикрин кислотасы — артиллериядә кулланыла торган шартлагыч, агулы кристаллик матдә.

ПИКТОГРА'ММА *и. лингв.* Берәр эш-хәрәкәтне, вакыйганы, әйберне, кешене һ. б. ш. сурәтләгән шартлы рәсем (иң борынгы язу формасы).

ПИКТОГРА'ФИК *с.* Пиктографиягә нигезләнгән. *Беренче язу уй-фикерләрне рәсемнәр аша аңлатудан башлана. Бу — пиктографик --- язу.* Х. Курбатов.

ПИКТОГРА'ФИЯ *и. лингв.* Пиктограмма ярдәмендә борынгы язу формасы.

ПИ'КУЛИ *и. махс.* Борыч, керән һәм бик вак итеп туралган яшелчәләр кушып маринадланган аш тәмләткеч.

ПИЛА *и. сөйл. к.* пычкы. *Шәйхи бер бик тирән Көрсенде дә кинәт Атып бәрде җиргә пиласын.* М. Җәлил.

Пила чүбе — *к.* пычкы вагы. — *Аз булмый, анда икенче кеше исемендәге --- кибеткә мал төямичә, пила чүбе тутырмаган.* Г. Камал.

ПИЛИГРИМ *и.* Изге саналган җирләргә гыйбадәт кылырга йөрүче, илгизәр кеше. *Һәр таң саен шуңа юлга чыгам — Мин тумыштан бирле пилигрим.* Н. Арсланов.

ПИЛМӘН *и.* Эче итле яки эремчекле, ә тышы төче камырдан булган бик вак бөккән (ул кайнап торган шулпага салып пешерелә). *Ит пилмәне. Эремчек пилмәне.* □ — *Пилмән камырына ничә күкәй сытарга [кирәк]?* Ә. Еники. [*Гайшә*] *табактан Шәяхмәт тәлинкәсенә пилмән сосып тора.* Г. Ибраһимов.

Пилмән бөгү — пилмән ясау.

ПИЛМӘНЛЕК *с.* Пилмән пешерергә яраклы. — *Менә карагыз, моның кай җирендә пилмәнлек кисәк булсын.* Соц. Тат. *Аңар эш хакы түлиләр: күлмәклек сатиннар, пилмәнлек ит һәм оннар...* Ш. Камал.

ПИЛМӘНХАНӘ *и.* Пилмән пешереп сатыла торган махсус ашханә.

ПИЛМӘНЧЕ *и.* Пилмән пешереп сатучы, кеше. [*Алар*] *иллешәр пилмән алдылар һәм, пилмәнче күз алдында ук чүгәләшеп утырып, сөйләшә-сөйләшә ашарга тотындылар.* Г. Минский.

ПИЛОН *и. махс.* Гөмбәз сыман корылмаларны тотып тора яки парк, күпер һ. б. ш. ларга керү урынына куела торган дүрткырлы юан, озын багана.

ПИЛОРА'МА *и.* Электромотор белән эшли торган янәшә пычкылар ярдәмендә такта яру җайланмасы. *Пилорама ягыннан гөрелте ишетелеп тора: анда яңа төзелешләр өчен такта яралар.* Г. Ахунов. — *Мин хәзер генә пилорама янында булдым. Деньга бүрәнә кайткан. Яра башладылар инде.* Г. Сәгыйдуллин.

ПИЛОТ *и.* Самолетны яки башка төр очу аппаратын идарә итүче кеше, очучы. *Диңгез пилоты.* □ *Гөлсем апа, --- тизрәк җитсен өчен, [хатны] аэропортка алып барып, тиздән Мәскәүгә китәчәк самолетның пилотына тапшырды.* Г. Гобәй.

ПИЛОТАЖ *и.* Очу аппаратын идарә итү осталыгы; самолётны маневрлау. *Югары пилотаж. Төркемле пилотаж.* □ [*Анисимов*], *пилотажның күренекле остасы буларак, ВВС башлыгы Яков Алкениска билгеле иде.* С. Баттал.

ПИЛО'ТКА *и.* Хәрбиләрнең козырёксыз, озынча формадагы җәйге җиңел баш киеме (элек пилотларда

гына булган). [*Нәфисә*] *каршысында --- пилоткасын кыңгыр салган, беләгенә кызыл хач бәйләп, янына дәү сумка аскан солдат дусты Гөлзәбәр елмаеп тора.* Г. Бәширов.— *Ипташ майор, мөрәҗәгать итәргә рөхсәт итегез,— диде* [*өлкән сержант*], *кулын пилоткасы янына кутәреп.* А. Шамов.

ПИЛОТЛЫК *и.* Пилот булу.— *Мин пилотлык эшен ярым-йорты гына беләм.* А. Тимергалин.

ПИЛТӘ *и. диал. к.* филтә. *Хәдичә лампа пилтәсен кутәрде.* А. Расих.

ПИЛЮЛЬ *и.* Сәдәф сыман итеп ясалган дару, таблетка.

ПИЛЮ'ЛЯ *и. к.* пилюль.— *Кыз тиз генә минем ярамны бинт белән бәйләп куйды. Авызыма ниндидер пилюля каптырып, графиннан стаканга су салып эчерде.* Н. Дәүли.— *Син, ипташ, нервыланган сың, пилюля кап, бик файдалы.* К. Тинчурин.

ПИЛЯСТР *и.* Бер ягы белән стенага кертеп ясалган дүрткырлы колонна. *Пилястрлар --- татарларда булмаган имеш, диләр.* Г. Шамуков.

ПИМА *и.* 1. *диал.* Киез итек. *Кыз, озын кунычлы пимасы белән йомшак карны ерып, күрше йортка чыкты.* Г. Ибраһимов. *Миңлегөлнең аякларында — үз сарыкларының йоныннан бастырылган соры пималар.* Ш. Камал.

2. Төньяк халыкларында: мех итек.

ПИМАЧЫ *и. диал.* Киез итек басучы кеше.

ПИНГВИН *и.* Ишкәк сыман аяклы, кыска канатлы, очмый, әмма яхшы йөзә торган зур диңгез кошы (Антарктидада яши). *Император пингвиннары.* □ *Авыраяк пингвиннар* [*зоопаркта*] *гомер итәләр.* Ж. Тәрҗеманов.

ПИНГ-ПОНГ *и. спорт.* Пластмасс тупчыкны озын өстәлгә аркылы тартылган тәбәнәк ятьмә аша фанер калакчыклар белән кара-каршы ыргытудан гыйбарәт уен; өстәл теннисы. *Баграт белән без пинг-понг уйнаганда танышкан идек.* Каз. утл.

ПИНЕР *и. иск. кит. к.* сыр II. *Ашарга бераз пинер вә икмәк алдык.* Ф. Кәрими.

ПИНЕ'ТКА *и.* Тәпи йөри башламаган балаларның йомшак күн аяк киеме.

ПИНЖӘК *и. сөйл. к.* пиджак. *Муса кадакны --- пинжәк чабуының капшалмастай бер җөве эченә яшереп куйды.* Ш. Маннур. *Аның сырлы тукымадан тегелгән пинжәге астыннан йонлач күкрәге күренеп тора.* Ш. Рәкыйпов.

ПИНЖӘКЛЕК *с., и. сөйл. к.* пиджаклык.— *Дә шул материалдан бер чалбар белән бер пинжәклек бирергә кирәк аңар.* Ш. Маннур.

ПИ'НИЯ *и.* Чатыр сыман ябалдашлы ылыслы агач; Италия нараты.

ПИНКӘ *и. диал.* Киндер сүсе, пәҗе. *Бауның өске кат бөртекләре тузып, өзелеп беткән була. Апа, әнем, мин шуларны мамыкландырганчы тетәбез. Моны бездә пинкә тету диләр.* Г. Гобәй.

ПИ'НТА *и.* Англия һәм АКШта сыек һәм бөртекле әйберләрне үлчәү берәмлеге (ул 0,56 литрга тигез).

ПИНЦЕТ *и.* Вак, тиз ватылучан һ. б. ш. әйберләрне кыстырып алу өчен медицинада һәм техникада кулланыла торган пружиналы эскәк. *Күз алмасының юка тиресеннән пинцет белән эләктереп алганнан соң, профессор кулындагы үткен пәке йөзе күз карасы тирәсенә тиде.* Э. Касыймов. [*Күршем*], *сыңар пыялалы лупа-күзлеген киеп алып, хирургныкы кебек пинцеты белән сагатемнең төртмәгән-капшамаган бер генә шөребен дә, бер генә кылын да калдырмады.* Р. Төхфәтуллин.

ПИ'НЧЕР *и.* Кыска йонлы, озын койрыклы һәм озын колаклы кечерәк эт токымы.

ПИНӘ *и. диал.* 1. Үпкә, кинә. *Пинә генәм зур, этием, үзеңә, Сабыйдан башка кияү тапмадың.* Җыр.

2. Шелтә, битәрләү. *Мулла булып зина кылгач, мужикларга юктыр пинә.* Г. Сәмитова.

ПИНӘЛӘТҮ *ф. диал.* 1. Үпкәләтү.

2. Шелтә белдерү, битәрләү. *Ат тотучым булдыклы кеше булганга күрә, пинәләтерлек эш күрсәтмәде.* Шура.

ПИНӘЛӘҮ *ф. диал.* 1. Үпкәләү, үпкә белдерү. *Су чапчагым тулмады-тулмады, Каенишкә пинәләдем, Үз бәхетем булмады.* Җыр.

2. Шелтәләү, битәрләү.— *Аның өчен мине пинәләмә, ул чакта мин аңламаганмын, хәзер инде төшенә башладым.* Ф. Сәйфи-Казанлы.— *Син мине үткән эш белән пинәләмә.* Ш. Хөсәенов.

ПИНӘҮ *ф. диал.* Үпкәләү. | *и. мәгъ. Нарасый сөйкемленең шундый пинәүләре мине кинәт чигендерә.* З. Бәшири.

ПИОН *и.* Ачык кызыл, ак һәм ал төстәге хуш исле әре чәчәкле декоратив үлән үсемлек; чалма чәчәк. *Мәдинәнең күзенә --- ап-ак пион чәчәге утыртылган ваза чалынды.* Ш. Хөсәенов. [*Сөләйманның*] *йөзе кызыл пион чәчәге төсенә керде.* К. Тинчурин.

ПИОНЕР I *и.* 1. Яңа, әле өйрәнелмәгән илгә, өлкәгә беренче буларак килеп чыккан һәм шунда урнашкан кеше.— *Себерне бит әле үзләштерә генә башладык. Без — юл ярып баручылар, пионерлар.* Г. Мөхәммәтшин.

2. *күч.* Фән-техника, сәнгать һ. б. ш. өлкәләрдә берәр эшне башлап җибәрүче, беренче булып яңалыкка юл салучы кеше. *Без әдәби һәм культура хәрәкәтебезнең пионерларын — Тукай, Камал, Әмирхан, Ибраһимовларны --- әледән-әле хөрмәтләп-олылап искә алабыз.* И. Рәмиев. *Кариев татар театрының беренче пионеры, үз эшенә чын күңелдән бирелгән фидакарь энтузиаст* [*иде*]. Г. Кәрам.

ПИОНЕР II *и.* Балаларның ирекле коммунистик оешмасы члены. *Әйдүк үзенең ипташларенә фронтларда йөрүен, хәзерге вакытта пионер булуын, тиздән комсомолга күчәчәген һәм коммуна мәктәбендә укуын берәм-берәм сөйләп бирде.* Һ. Такташ. || *сөйл.* Шул оешма үзе. *Сезнең гомер*[*дә*] *--- шатлыклы ике вакыйга булып үтте: беренче көнне мәктәпкә бару, пионерга керү.* Г. Гобәй. *Пионерда үтте балачагым, отряд йөрткән байрак астында.* Г. Хуҗи. || *с. мәгъ.* Пионерларга (II) хас.

Пионер костёры — пионерларның янып торган учак янында тантаналы рәвештә күңел ачуы. **Пионер лагере** — гадәттә җәй көне пионерлар һәм гомумән мәктәп балалары ял итү өчен махсус җиһазландырылган лагерь.

ПИОНЕРВОЖА'ТЫЙ *и.* Мәктәптә, балалар йортында, пионер лагеренда пионер отряды яки дружинасы белән җитәкчелек итүче яшь кеше. *Монда якын елларда укытучы-тәрбияче яки пионервожатый булып эшләячәк яшь кызлар, яшь егетләр җыелган.* Г. Бакиров. *Укытучылар бүлмәсеннән өлкән пионервожатый Халидә чыкты.* Ш. Рәкыйпов.

ПИОНЕ'РИЯ *җый. и.* Пионерлар II.

ПИОНЕРЛА'РЧА *рәв.* Пионерларга (II) хас булганча, пионерлар (II) кебек.— *Иптәшләр, бөтен республикага билгеле булган сезнең „Йолдыз" отрядына бездән пионерларча сәлам.* А. Алиш.— *Син, Хәкимҗан, чын пионерларча эшләгәнсең. Ферма күкәйләрен китерүең әйбәт эш ул.* А. Әхмәт.

ПИОНЕРЛЫК I *и.* Пионер (I) булу. *Җир асты тимер юлы эшендә Париж эшчеләре бөтен дөнья күләмендә пионерлык ролен уйныйлар. Бу юлда Париж инженерлары бөтен дөньяга сабак бирәләр.* Г. Гали.

ПИОНЕРЛЫК II *и.* Пионер (II) булу. *Син — беренче чиратта пионер һәм син бу эшең белән чын пионерлыгыңны күрсәттең.* Г. Гобәй.

ПИОНЕ|РЧА *рәв. сир. к.* пионерларча.— *Пионерча буламы соң бу?* Г. Гобәй.

ПИПЕЛДӘҮ *ф.* „Пип-пип" дигән аваз, тавыш чыгару. *Егерме бәбкә --- су өстендә тәпиләрен тидерер-тидермәс йөгерешеп үтәләр, егермесе дә шуны эшли алганга, әллә нинди куанычлы тавышлар чыгарып пипелдиләр.* Н. Исәнбәт. *Эфирда радио позывнойлары пипелди башлый.* Ә. Маликов.

ПИПЕ|ТКА *и.* Сыеклык суыртып алу һәм аны тамчылап агызу өчен кулланыла торган резина башлы нечкә пыяла көпшә; тамызгыч. *Менә ул әлеге әремәне пипетка белән тиешле күләмдә үлчәп ала.* Ә. Касыймов.

ПИ-ПИ *аваз изл.* Каз бәбкәләре, чебиләр, вак кошлар кычкырганда яки радиосигналлар биргәндә чыккан тавышны белдерә. *Яшел чирәм өстендә пи-пи дип йөгерешкән сары каз бәбкәләре дә рәсемгә ясап куйган кебек күз алдында торалар.* Н. Дәүли. *Морзе елый — пи-пи, пи-пи,— Адашкан чеби сыман: Пи-пи, пи-пи,— заданиене Үтәп кайтып киләбез.* С. Баттал.

Пи-пи итү (килү) — шундый аваз, тавыш чыгару. *— Абыем, [акчарлак] ник пи-пи итә?* Г. Гобәй. *Каз бәбкәләре --- озын борыннары белән үләнгә үреләләр, үзара пи-пи киләләр.* Г. Галиев.

ПИПИ *и. диал.* 1. *к.* песи (2 мәгъ.). *Алар язгы урман һавасын суладылар, яр буенда саргылт тал пипиләре өзделәр.* Н. Фәттах.

2. Каз яки үрдәк бәбкәсе.

ПИП-ПИП *аваз изл. к.* пи-пи. *Бәбкәләр ашап туя, Иркә кагынып куя: „Пип-пип-пип-пип-пип!"* Ш. Маннур. [*Каз*] *нәзек кенә „пип-пип" дигән тавышны ишетүе була, урамга чыгу кайгысын шундук онытып та җибәрә.* Г. Бәширов.

ПИР I *и. иск. кит.* 1. Карт, күп яшәгән кеше.

2. Бер төркем фикердәшләрнең башында торучы, җитәкче кеше; шәйх. *Күтәрдек без ул Дәһины Барлык дөнья эшчесенең пире итеп.* З. Бәшири. [*Җантимер*] *йортта өлкән пир иде.* Сов. әд.

ПИР II *и. диал. к.* пәри. [*Айтүтә*] *ата-баба йоласын да онытмады: пир алмаштырмасын дип, бала бишегенә тимер кисәге куйды.* Г. Әпсәләмов.

ПИРА-ЗИРА: пира-зира килү (китерү) *диал. к.* пыран-заран килү (китерү). *Бөтен максат һәм якты хыялларың, бөтен эшең пира-зира килеп, үзең берни эшли алмыйча җирдә аунап ятуның ачы үкенеченә ничек түзәргә?* Ш. Маннур. [*Эт*] *ботканы пира-зира китереп чәчеп бетерә.* Әкият.

ПИРАМИ|ДА *и.* 1. *мат.* Нигезе өч яки күппочмактан, ә ян яклары уртак түбәле өчпочмаклардан торган геометрик җисем — күпкырлык. *Бишкырлы пирамида.* □ *Тау хрусталенең кристаллары үтәдән-үтә күренә, алтыпочмаклы пирамидалар кебек очлаеп тора.* Ж. Тәрҗеманов.

2. Борынгы Мисыр фиргавеннәренең (патшаларының) каберләре өстенә төзелгән һәм нигезе дүртпочмактан, ә ян яклары бер түбәгә тоташкан өчпочмаклардан торган гаять зур таш корылма. *Хеопс пирамидасы.* □ *Мисыр пирамидаларын кемнәр белми? Ул тау кадәр кабер һәйкәлләрен йөз меңләгән коллар салганнар.* Н. Дәүли.

3. Югарыга таба очланып килә торган киң нигезле предмет. *Кабер өстенә [алар] чардуган коралар, баш очына йолдызлы пирамида утырталар.* Г. Ахунов. || Шул рәвешле өелгән әйберләр.

4. Бер-берсе өстенә басып торган кешеләрдән гыйбарәт гимнастик яки акробатик фигура. *Эшче яшьләр физкультура киемендә --- җирдә мәтәклиләр, пирамидалар ясыйлар.* Ш. Камал. *Ул пирамида дигәне болай: сәхнәдә бер-береңнең җилкәләреңә басып, бер-береңне кулларда күтәреп, катлы-катлы булып басасың.* Р. Төхфәтуллин.

5. 16 шарлы бильярд уены; шул уен башланыр алдыннан өчпочмак итеп тезелгән бильярд шарлары.

6. *хәрби.* Мылтыклар саклар өчен алды ябусыз шкаф яки пирамида (1 мәгъ.) сыман кечерәк җиңел корылма; көпшәләре бергә каратып утыртылган мылтыклар. *Бүген дневальный булып утыручы сипкелле йөзле Петросян пирамидага тезелгән мылтыкларны тагын бер кат тикшереп чыкты.* К. Нәҗми. *Ул бөтен сугышчыларын пирамида янына җыйды да затворлары ачылып пирамидага куелган мылтыкларны берәм-берәм алып карый башлады.* М. Әмир.

ПИРАМИДАЛЬ: пирамидаль тополь — формасы белән пирамидага (1 мәгъ.) охшаган, өскә таба очланып торган тополь. [*Митрофан*] *Днепрны, су кебек якты айлы кичләрне, пирамидаль тополькларне күз алдыннан үткәрде.* Г. Ахунов. *Нинди матурлык һәм тынлык хөкем сөрә монда. Пирамидаль тополькләр, искиткеч хуш исле үлән, төрле төстәге утлар...* Каз. утл.

ПИРАМИДОН *и. махс.* Авыртуны баса һәм температураны төшерә торган дару. *Ул Мәдинәгә нидер пышылдады да, пирамидон эчәм дигән булып, китә башлады.* Ш. Хөсәенов. *Аның башы авыртып тора икән, пирамидон белән кара кофе эчеп, бераз ятып торса, бәлки, рәтләнеп тә китәр.* Ш. Маннур.

ПИРАТ *и. тар.* Диңгез юлбасары. *Куркытмады безне пиратлар, Шаулап барды безнең кораблар.* Ә. Исхак. *Читтән караганда, алар диңгездә кораб талаганнан соң качып китеп баручы урта гасыр пиратларын хәтерләтәләр.* Г. Ахунов. || *күч.* Чит җиргә басып керүче, илбасар, башкисәр. *Һава пиратларын буар өчен, [очучылар] Яшен булып күккә менәләр.* Г. Күтүй. *Немец фашистларының су асты пираты монда кадәр килеп җитә һәм. юлбасарларча ташланып, пароходларны батыра башлаганнар иде.* С. Сабиров.

ПИРАТЛЫК *и.* Пират булу, пиратлар эше.— *Габдрахман пиратлыкка чыгып китмәкче [була].* М. Юныс.

Пиратлык итү — диңгездә юлбасарлык итү, талау. [*Бу сатлык җан*] *ерак океаннарда пиратлык итә торган су асты көймәләреңә --- кую өчен эшләнгән куәтле радиоалгычларны сыный.* Ш. Маннур.

ПИРЕ *и. бор.* Күп башлы елан төсендәге кеше ашаучы явыз җан иясе, дию пәрие. *Син сөйлисең пирегә, пире сөйли киребез.* Мәкаль.

ПИРЕС *и. иск.* Ефәк. || *с. мәгъ.* Ефәк тукымадан тегелгән. *Кара пирес түбәтәй, Кәләш алып бир, әтәй.* Г. Тукай.

ПИРЕ|ТРУМ *и.* Ромашканың кайбер төрләреннән ясала һәм авыл хуҗалыгы корткычларын, тарактагы паразитларны юк итү өчен кулланыла торган саргылт сары төстәге порошок. *Баланың шактый керләнгән күлмәк якасына пиретрум сиптеләр дә санобработка үтте дигән әзер кәгазь кисәге тоттырдылар.* Г. Гобәй.

ПИРИТ *и.* Күкерт яки тимер колчеданы. *Ялтыравык сары кубиклы пиритны --- үлчәү нәтиҗәсендә көтелмәгән җавап килеп чыкты.* Ж. Тәрҗеманов.

ПИРОГ *и. сөйл.* Бәлеш, бөккән. *Якуб, бер кисәк пирог, бер кувшин сөт алып, яр буена ашарга утырды.* И. Гази.— *Кәбестә пирогы телисеңме?* Г. Гобәй.

◇ **Пирог башлы** — озынча башлы (кеше турында). *Пирог башлы, тар маңгайлы --- казылыкчы Хәйрулланың күренүе дә мәҗлескә яшерен притон төсе бирә иде.* К. Тинчурин.

ПИРО'ГА *и.* Океания халыкларында һәм караибларда: тире яки агач кайрысы белән тышланган яисә агач кәүсәсен чокып ясалган озын тар көймә; каек.

ПИРОЖКИ *и. сөйл.* Вак бөккән, сумса. *Нәгыймә апа --- иртәнге чәйгә кайнар пирожкилар өлгертер өчен, торып, камыр куйды.* Г. Кутуй.

ПИРО'ЖНЫЙ *и.* Сөт-май кушып изелгән күзәнәкле камыр арасына татлы нәрсә (мәсәлән, миндаль, крем һ. б. ш.) салып пешерелгән кондитер ашамлыгы. *Бисквит пирожные. Катлы пирожный.* □ *Хатын-кызлар кофе, шоколад, пирожныйлардан авыз итәләр.* Ш. Камал. *Кибеттә пирожный алып, күбрәк ашап ташлаган идем.* С. Баттал.

ПИРОКСИЛИН *и.* Шартлату эшләре һәм төтенсез дары ясау өчен кулланыла торган матдә.— *Бик узына башласагыз, һәркайсыгызның каморкасын пироксилин белән күтәртербез!* К. Нәҗми. *Пироксилин, нитроглицерин, динамит — һәммәсе шул чаклы күп, әгәр ялгыш ут төшә калса, бөтен кварталны күккә күтәрәчәк.* Г. Ибраһимов. || *с. мәгъ.* Шундый матдәдән ясалган. *Пироксилин шашка.*

ПИРО'МЕТР *и.* Югары температураларны үлчи торган прибор.

ПИРОМЕ'ТРИЯ *и.* Югары температураларны үлчәү турындагы тәгълимат.

ПИРОП *и.* Кызыл төстәге асылташ, гранатның бер төре.

ПИРОТЕ'ХНИК *и.* Пиротехника буенча белгеч. *Яшь пиротехникны* [*бу шартлату*] *өчен карцерга ябалар.* Ж. Тәржеманов.

ПИРОТЕ'ХНИКА *и.* Техниканың тиз кабынып китүчән матдәләр, сигнал утлары, ракеталар һ. б. ш. нәрсәләр хәзерләү белән шөгыльләнә торган бүлеге.

ПИРР: Пирр җиңүе — бик күп корбаннар таләп иткән, шуңа күрә дә җинелүдән әллә ни аермасы һәм бернинди файдасы булмаган җиңү (Эпир патшасы Пиррның бик зур корбаннар белән римлыларны җиңүеннән соң әйтелә башлый).

ПИРС *и. махс.* Корабльләр килеп туктар өчен яр кырыеннан суга эчкәрәк кертеп эшләнгән корылма. *Дә бөкре Рас-Зыярәт борыны, дулкын тоткарлагыч һәм зур пирс күренде.* Р. Мостафин. *Көчле бер буксир зур корабны пирслар арасыннан порт уртасына сөйрәп чыгарды.* Каз. утл.

ПИРУЭТ *и.* Танец вакытында бер аяк очына басып үз тирәндә бер кат әйләнеш. [*Кәбир*] *балериналарның матур пируэтлар яса*[*вына*] *--- соклан*[*ды*]. Ш. Хөсәенов.

ПИРӘШ *и. иск.* Исерткеч эчемлек. *Азрак эчкәч, башка киткәчтән пирәш,— Кемгәдер ул иске серне итте фаш.* Г. Тукай.— *Махсус заказ — милли кабартма да пешерелде. Мунчадан чыгуга пирәш тә бар.* К. Тинчурин.

ПИРӘШЛӘҮ *ф. иск. сөйл.* Бик кәефләнеп эчү, исерү, исерткеч эчеп кәеф-сафа кору. *Дәмин ага куерып кына пирәшләп кайтып килә иде. --- Аңа бөтен урам йөри шикелле тоела.* Г. Газиз. [*Гарәфи:*] *Юлда бик яхшы бардык.* [*Сиражәтдин:*] *Бик дөрес, хәтта --- бергә пирәшләдек тә.* Г. Камал.

ПИС *с. иск. кит.* Әшәке, кабахәт, пычрак, түбән (кеше, эш, мохит һ. б. ш. турында). *Шундый күңелсез тормышта, пис мохиттә яшәсә дә, шагыйрьнең таланты бәреп чыга.* Ш. Әхмәдиев. *Яхшылыкны пис кеше белмәс.* Мәкаль. || *и. мәгъ.* Әшәке, кабахәт кеше. — *Кит, сиңа ләгънәт!.. Күгемнән кит!* — *диде.*— *Бар, хәзер шайтанга баш бул, пис!* — *диде.* Ш. Бабич.

ПИ'САРЬ *и. сөйл.* Канцеляриядә язу-сызу эшләре белән шөгыльләнүче түбән дәрәҗәдәге хезмәткәр. *Волость писаре. Полк писаре.* □ — *Без менә үзебез, урысча укымагач, прошениеме, адресмы язарга кирәк булса, әхмәтша учительгә, я судтагы писарьга йөгерәбез.* Ә. Фәйзи. *Бер якта штаб писаре нәрсәдер язып маташа.* Н. Дәүли.

ПИ'САРЬЛЫК *и. сөйл.* Писарь булу.— *Әйдә, берәр писарьлыкка булса да ярармын әле. Мине дә ал инде.* Ш. Усманов. *Мин бу писарьлык эшеннән ничек кенә булса да* [*китәргә*] *ниятләп куйдым.* Ә. Еники. || Писарьларга хас гадәт, күнекмәләр.

ПИ'СЕР *и. сөйл. к.* писарь. *Исемлек укый писер. Исеме юк байларның.* Ә. Давыдов.— *Әйдә, писер булып гел язулар гына язып йөрмә әле.* Г. Бәширов.

ПИ'СЕРЛЕК *и. сөйл. к.* писарьлык.— *Соңыннан* [*Гомәр морза*], *бик картайганга күрә, писерлегеннән төште.* Г. Камал.

ПИСЛЕК *и. иск.* Әшәкелек, кабахәтлек, түбәнлек. *Тугры килгән урыны чүплеккә, тиреслеккә аныңКаплап алган төрле шакшы, төрле пислек һәр ягын.* Г. Тукай. *Кая баксаң да пычраклык вә пислек.* М. Гафури.

ПИССУАР *и.* Ирләр бәдрәфендә сидек агып төшәр өчен торбасы булган махсус чүлмәк-савыт.

ПИСТОЛЕТ *и.* Чагыштырмача якындарак торган җанлы-җансыз нәрсәләргә ату өчен кечкенә генә кул коралы. *Кеше, күзләрен Акбүздән алмыйча, уң кулын әкрен генә кесәсенә шудырып, имән бармагын пистолет курогына тыкты. Һәм пистолетын чыгарып Акбүзгә төзәде.* Г. Гобәй. *Нәҗия пистолетыннан аның өстенә тагын утлы чаткылар чәчелде. Гроссман гөрселдәп ауды.* Н. Дәүли.

ПИСТОЛЕТ-ПУЛЕМЁТ *и.* Якын арага бик тиз ату өчен кулланыла торган автоматик корал; автомат. *Лейтенант Орлов --- пистолет-пулемёттан тырылдатып атып җибәрде.* Ә. Маликов.

ПИСТОЛЬ *и. иск. к.* пистолет. *Сәхип абзый, күзенә махсус күзлеген киеп, элек пистольне карады: „Д, иске икән. Яхшы пистолет, яхшы“,* — [*диде*]. Г. Газиз.

ПИСТОН *и.* **1.** Ударник (I) белән бәрдергәч, патрон эчендәге зарядны кабыза торган шартлагыч матдәле кечерәк металл капсюль (ул гильза төбендә була). *Сәхип солдат --- атайга ике пистон бирде һәм, атайның бик курыкканын күреп: „Юк ла, курыкма, атылмый бит ул, менә* [*моны*] *киертсәң генә ата...“— ди*[*де*]. Г. Газиз. *Мылтык атылмаган: әллә нәрсә генә булган — әллә дары дымыккан, әллә пистон бозылган.* Ш. Маннур. || Уенчык мылтыклардан, пистолетлардан ату өчен эченә бераз дары салып ябыштырылган түгәрәк кәгазь. *Минем портфелемә --- пистон шартлата торган „револьвер“* [*сыя*]. Г. Галиев.

2. Катыргы яки күн әйберләрнең (мәсәлән, ботинканың) тасма үткәрер өчен тишелгән тишекләренә механик ысул белән беркетелгән тимер кыса.

3. *муз.* Тынлы җиз музыка коралында клапан.

ПИСТОНЛЫ *с.* Пистон белән ата торган (корал турында). *Пистонлы мылтык.*

ПИТЕКА'НТРОП *и. махс.* Үзенең табигый үсешендә кеше һәм кешесыман маймыллар арасында торган бик борынгы казылма зат; маймыл-кеше.

ПИТИЛ *и. сөйл.* Балыкларны читкә җибәрмәү өчен ике ягында ике канаты булган, мурда шикелле ау коралы.

ПИТО'МНИК *и.* Үсемлекләр, хайваннар яки балыклар үрчетү, үстерү урыны. *Шәрифҗан агай --- ике питомникта икеләйләп мең төп алмагач үстерә.* М. Максуд. *Питомниктан алып кайтып, яңа төр балыклар җибәрдек.* Г. Гобәй.

ПИТОН *и.* Буар еланнар төркеменнән тропикта яши торган агусыз эре елан. *Гыйззәтуллин, питон авызына үз ихтыяры белән кереп барган гипнозланган куян шикелле, берни аңламыйча аның артыннан кабатлый.* М. Мәһдиев.

ПИТРАС *и. диал. к.* питрач.— *Бәй, питрасны миннән сора аны,* [*балам*]. Г. Әпсәләмов.

ПИТРАСЛЫК *с. диал. к.* питрачлык. *Бер питраслык камыр.*

ПИТРАУ *и. иск.* Русларның иске стиль буенча 29 июньдә була торган дини бәйрәме.— *Башка елларны [чебеннәр] көзгә таба гына каты тешли торган иделәр бит, әкият. Әле питрау җиткәне юк лабаса.* Ш. Камал.— *Тиздән тургайлар сайраудан туктыйлар, белдеңме? Питрау гына җитсен.* А. Гыйләҗев.

Питрау көн — *к.* питрау.— *Питрау көнне өйлә соң питрау үләне җыя торган йола юк ул.* М. Гали.

Питрау тәкәсе — 1) махсус симертеп, печәнгә төшкәндә суела торган яшь тәкә; 2) *күч. мыск.* бик ныклы симергән һәм маена чыдый алмый чытлыклана башлаган ират турында; 3) *күч. мыск.* кызлар артыннан йөри башлаган яшүсмер.

Питрау үләне — им-том өчен питрау алдыннан җыела торган үлән үсемлек.— *Питрау үләне җыярга дип кырга чыккан идек, ике җир арасыннан зәңгәр чәчәкләр җыйгач, инде урманга кереп, әзрәк мәтрүшкә дә җыеп чыгыйк дип, шушы түгәрәк алан тирәсенә кил[дек].* М. Гали.

ПИТРАЧ *и. диал.* 1. Икмәк салганда куәс төбендә калган камырдан пешерелгән кечкенә түгәрәк ипи; кырындык, игәрче.— *Миңа бит табаклап он яки питрач булса да ярый.* Шура.

2. Төче камырдан пешерелгән вак күмәч.

ПИТРАЧЛЫК *с.* Питрачка дигән, питрачка җитәрлек. *Өч питрачлык камыр.*

ПИЦЦИКА'ТО *муз.* 1. *рәв.* Кыллы музыка коралында бармак белән чиертеп (уйнау турында). *Бу күңелле кисәктә кыллы инструментларның бик эффектлы рәвештә пиццикато — бармак белән чиертеп уйнавы --- урамда балалайка чиертеп, җырлап узучы күңелле мужикларны --- күз алдына китерә.* Җ. Фәйзи.

2. *и.* Музыка әсәренең бармак белән чиертеп уйнала торган өзеге.

ПИЧ *и. диал. к.* мич.— *Икмәкне пичтән генә чыгардым.* Ф. Бурнаш. [*Карчык*] *оекларын, перчаткаларын әле генә томаланган пич башына кибәргә куйды.* Г. Галиев.

Пич аралыгы (арты) *диал.*— мич белән стена арасындагы (гадәттә инә бер метр тирәсе) аралык. **Пич асты** *диал.*— зур мич астында утын, кисәү һ. б. әйберләр тутыру өчен калдырылган куышлык. *Пич астыннан песи чыкты прахлап.* Г. Тукай. **Пич ашы** *диал.*— бәлеш, кабартма кебек мичтә пешерелә торган аш-су. **Пич башы** *диал.*— зур мич өстендә әйбер киптерер, кеше йоклар өчен калдырылган киң урын; мич башы. *Борын-борыннан киез итекнең урыны пич башы аның.* Ш. Хөсәенов. *Пич башында катлы-катлы бөркәнеп яткан әби.* Ш. Бабич. **Пич камакышы** *диал.*— мич көймәсе. **Пич кашы** *диал.*— мичнең кечерәк әйбер куяр яки киптерер өчен бөтен буена ярты кирпеч чыгарып ясалган сыры; кучкар. **Пич такта(сы)** *диал.*— мич капкачы. *Тешсез бака — пич такта, пич астында тик ята.* Такмак. **Пич түбә** *диал.*— мич башы.

ПИЧТӘЙ-ТУЧТАЙ *и. сөйл. сир.* Олы гәүдәле симез кеше.

ПИЧӘТ *и. сөйл.* 1. *к.* печать (1 мәгъ.).— *Менә бу мәгълүматларга кул куеп, пичәт суксаң, иртәгә волостька җибәрер идек.* Ш. Маннур.— *Хәзер үк справка язарга да Зиннәттән пичәт суктырып алырга [кирәк].* Г. Насрый.

2. *у.-вак. килеш.* **пичәттә.** Берәр бина (квартира, кибет, склад) һ. б. ш. ишегенә печать басылып, аңа рөхсәтсез керү, аннан файдалану тыелган булуны белдерә. *Касимский Ибрайның өч кибете пичәттә.* Г. Сәмитова.

◇ **Пичәт бастыру (суктыру)** — берәр сүзне расларга, дөресләтү, җөпләтү. [*Мортаза*] *бер нәрсә сөйли башладымы, хатынына эндәшеп: „Әйеме, әнисе?“, „Шулай бит, Зөләйха Фәрдиевна“, „Үзең дә шулай дигән идең бит, карчык“,— дип, һәр җөмләсенә пичәт бастырып торды.* Б. Камалов. **Пичәт басу (сугу)** — 1) кемнең дә булса сүзен раслау, дөресләү, җөпләү. *Мөнир һаман бер төрле җаваплларга пичәт сугып утырды.* А. Гыйләҗев; 2) берәр нәрсә яки кеше турында ныклы фикергә килү. *Д үзем әллә кайчан пичәтне басканмын: „Юк, рәт чыкмас бу шайтан малайдан!“* Ф. Хөсни.

ПИЧӘТКӘ *и. диал. к.* перчатка. *Ызба артында — рәшәткә, Кулда — яшел пичәткә.* Җыр.

ПИЧӘТЛЕ *с.* Пичәт басылган (кәгазь, шешә авызы һ. б. ш. турында).— *Җәннәттә мөселманнарга пичәтле аракылар эчерерләр, [имеш]!* Г. Гобәй.— *И, Ясәви әнем, карчык кеше бит инде ул, әлсерәгән кортка! Анда пичәтле кәгазь кайгысымыни?* Г. Бәширов.

ПИЧӘТЛӘҮ *ф.* 1. *к.* печатьләү (1—2 мәгъ.).— *Хәзер сез барып [аның] келәтен пичәтләп кайтыгыз.* һ. Такташ.

2. Бал тутырылган кәрәз күзәнәкләрен балавыз белән каплау.— [*Бал кортлары*] *рамаларны бөтенләй пичәтләп бетергәннәр, урын булмагач, планка буйларына бал сала башлаганнар.* Г. Галиев.

ПИШЕР *и. диал.* Балта осталары коралларын тутыру өчен юкә кабыгыннан ясалган тар тубал.

ПИШКАДӘМ *и. иск.* 1. Укуда башкалардан алда булган шәкерт.

2. Иске мәдрәсәнең тулы курсын тәмамлаган хәрмәтле кеше. *Сәлах хәзрәт мәдрәсәсеннән Исмәгыйль дигән „бик гыйльми“ бер пишкадәмне мулла итеп куйганнар.* Г. Камал. *„Пишкадәм“ дигән исемне --- алган шәкерт, гәрчә аның белеме ике бозауга кибәк аерырга яраклык булмаса да, галимлекнең иң соңгы дәрәҗәсенә җиткән санала.* З. Бәширн.

ПИШКАДӘМЛЕК *и.* Пишкадәм булу. *Мин пишкадәмлек дәрәҗәсенә ирешкәч, авылга өченче мәчет салынып, мин шунда мулла --- булачакмын икән.* З. Бәширн.

ПИШТӘР *и. диал. к.* биштәр. [*Карт*] *аркасына ку, чакма вә башка сәфәр әсбаплары салынган пиштәрне ас[ты].* Шура.

ПИШӘЮ *ф. иск.* Үзен зур күрсәтү, масаю, горурлану.

ПИЯШ *и. диал.* 1. Мич янына куела торган нәзек терәк багана (сәндерәне яки шүрлекне тотып тору, чаршау бавын бәйләү өчен кулланыла). *Тик торган пияшкә берәү дә кагылмый.* Мәкаль.

2. *күч.* Ялгыз юаш кеше турында әйтелә.

ПЛА'ВИК: плавик кислотасы — пыяланы ашый торган көчле кислота. **Плавик шпат** — төссез һәм төсле кристалл рәвешендәге минерал (металлургиядә, химия промышленностенда, оптикада һ. б. кулланыла).

ПЛА'ВКИ *и.* Су кергәндә яки кызынганда киелә торган бик тар һәм кыска трусик. *Ул, гадәтенчә, плавки гына киеп йоклаган.* Г. Мөхәммәтшин.

ПЛАГИАТ *и.* Башка автор әсәрен яки хезмәтен тулысынча яки аерым өлешләрен үзенеке итеп бастырып чыгару; әдәби караклык. *Бер „шәп мөхәррир“ булырга [чын теләк] белән керешкән кеше плагиатта тотылды.* Г. Тукай.

ПЛАГИАТЧЫ *и.* Плагиат белән шөгыльләнүче кеше, әдәби карак.

ПЛАГИАТЧЫЛЫК *и.* Плагиат белән шөгыльләнү, әдәби караклык. *Плагиатчылык белән чикләнә торган мондый „хезмәт“кә оятсызлык дигән исем генә бирергә мөмкин.* А. Гомәр.

ПЛА'ЗМА *и.* 1. *биол.* Канның сыек өлеше, кан сүле. *Яралгы плазмасы. Кан плазмасы.*

2. *физ.* Бик нык ионлашкан, барлык кисәкчекләре дә ионлашып беткән матдә (мәсәлән, Кояш, шар сыман яшен).

3. *с. мәгъ.* Шул матдәне өйрәнүгә һәм файдалануга бәйләнешле. *Плазма химиясе. Плазма техникасы.* || Шул матдәне файдаланып эшли торган. *Плазма генераторы. Плазма двигателе.*

ПЛАЗМА'ТИК *с.* Плазмадан гыйбарәт. *Күзәнәкләрдәге плазматик матдә. Плазматик яры.*

ПЛАЗМО'ДИЙ *и. биол.* Паразитик рәвештә канда яши һәм бизгәк авыруы тудыра торган лайлалы төер сыман иң гади организм.

ПЛАКАТ *и.* Агитация, белешмә яки реклама өчен урамнарда, җәмәгать учреждениеләрендә эленә торган, гадәттә эре хәрефле, рәсемле язу. *Плакатта егет: „Кил безгә",— дип Чакырып тора мине ерактан.* М. Җәлил. *Бер плакат колхозчыларның игътибарын аеруча үзенә тартты: зур иттереп кукуруз чәкәне ясалган.* Э. Маликов. || Кыскача язма игълан. *Тролейбуслар „Иделдә боз кузгалды!" дигән плакатлар тагып йөри башладылар.* Г. Ахунов.

ПЛАКАТЧЫ *и.* Плакатлар ясаучы рәссам.

ПЛАКАТЧЫЛЫК *и.* Сәнгатьтә эчтәлеккә зарар китерү хисабына тышкы күренешләр белән артык мавыгу. *Карамышева, Позднякова иптәшләрнең гомумән яхшы уйнауларын әйткән хәлдә, аларның һаман элекке „плакатчылык", „курчак уены" традицияләрен саклауларын күрсәтергә кирәк.* М. Җәлил.

ПЛАКЕ'ТКА *и. махс.* 1. Турыпочмак рәвешендәге медаль.

2. Өсте кабарынкы рәсемнән гыйбарәт такта кисәге (мебельгә ябыштырыла).

ПЛАКИРЛАУ *ф. махс.* Су юудан саклау өчен сөзәк жирләрне, туфрак өемнәрен кәс белән каплау. *Болак буен плакирлау.*

ПЛАН *и.* 1. Берәр урын, корылма, әйберләрнең, пропорцияләрен саклаган хәлдә, кәгазьгә төшерелгән масштаблы сызымы. *Шәһәр планы. План сызу.* □ *Иптәшем ясап биргән планга караганда, бу йорт Гариф әфәнде тора торган йорт булырга тиеш иде.* Ф. Әмирхан. *Гали абзый, планга карап, колхоз җиренең кырыйларын күрсәтә.* Г. Әпсәләмов.

2. *диал.* Йорт урыны.

3. Сәхнәдә берәр әйбернең (җиһазның) тамашачыдан ерак яки якын торышы, тамашачы күзлегеннән карагандагы торышы. *Сәхнәнең арткы планында бер татар авылы күренә.* Ф. Бурнаш. *Алгы планда — ишеге белән тамашачыларга карап торган иске каравыл өе.* Т. Гыйззәт. || *махс.* Экрандагы сурәтләрнең зурлыгы-кечкенәлеге. *Артистның зур планда бирелеше.*

4. *күч.* Предметның әһәмиятлелеге, кирәклеге ягыннан тоткан урыны турында. *Безнең киләчәк буыннар хатын-кызларны хатын булган өчен генә түгел, ә кеше булган, иптәш булган, бөек төзелештә бергәлләп эшләгән өчен сөярләр. Билгеле, матурлык, гүзәллек мәсьәләсе арттагы планга китәчәк түгел.* А. Шамов.— *Мул уңыш белән мәктәп эше, тәрбия эше һәрвакыт бер рәттә, беренче планда торырга тиеш.* Р. Ишморат.

5. Билгеле бер максатны күздә тотып башкарыла торган эш-чараларның тәртибе, эзлеклелеге, сроклары, күләме, алдан уйлап куелган системасы. *Халык хуҗалыгы планы. Бишьеллык планны срогыннан алда үтәү. Эш планы. Чәчү планы. Планнан тыш.* □ *— Ленин исемендәге колхоз урып-жыю планын дүрт көн алдан төгәллә.* Р. Ишморат. *Бу тирәдәге авылларга газның якын елларда ук кертелүчән дә әйтәләр. Планда шулай каралган, диләр.* Г. Галиев. || *с. мәгъ.* Эшнең шундый системасын төзү белән шөгыльләнә торган. *План бүлеге. План органнары.* || *с. мәгъ.* Эшнең шундый системасы буенча күздә тотылган яки эшләнелә торган. *План заданиесе.*

6. Берәр нәрсә турында язу яки сөйләү тәртибе. *Изложение планы.* □ *Бу либреттоның темасы һәм планы - - - композиторлар киңәшмәсендә тикшерелгән иде.* М. Җәлил. *Ул вакытта бәлки драманың бөтен планын үзгәртергә кирәк булган булыр иде.* Г. Камал.

7. Берәр нәрсә эшләргә ният, уй. *Авылның үз халкын да күбрәк катнаштырып, совхозга экскурсия ясарга теләсәк тә, бу планыбыз тормышка аша алмады.* М. Әмир.— *Син бит белмисең әле минем нинди планнар белән йөргәнне: бакчаны җиләк-жимеш белән күмәргә уйлыйм мин.* И. Гази.

8. Берәр нәрсәгә, мәсьәләгә караш, берәр мәсьәләне, нәрсәне тикшерү, эшләү, башкару, ясау юнәлеше, яссылыгы. *Мәсьәләне теоретик планда карау.* □ *„Ак чәчкә бабай" [шигыре] - - - 15 нче елда җитди протест төсендә язылса да, 17 нче елда юмор планында яңадан эшләнде.* Н. Исәнбәт. *„Койрыклы йолдыз" — көнкүреш планында куелган фильм.* Н. Юзиев.

План белән — алдан уйлаганча, алдан уйлаган тәртиптә.— *Розакай, зинһар, борчылма, барысы да план белән бара.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Һәрбер эш план белән, Ат сукалый ызан белән.* Әйтем. **План кору** — киләчәктә нишләргә кирәклеге турында алдан уйлау; алдан сөйләшеп килешү.— *Шәрифә әбине синең чанага салып җибәрергә алдан ук план корган идек без.* А. Шамов. [*Шәкертләр*] *идарә аркылы яхшы урын, бай мәхәллә табарга план коралар.* Г. Ибраһимов. **Планга утыру** *иск.*— планлы рәвештә урнашу, билгеле бер план буенча төзелү, салыну (йортлар, каралтылар турында).

ПЛАНЁР *и.* Күтәрелмә һава агымнары ярдәмендә моторсыз оча торган аппарат.— *Карандашларыгызны очларсыз. Кораблъләр ясарсыз, планёрлар.* Д. Аппакова. || *с. мәгъ.* Шундый аппаратны очырту белән бәйләнешле. *Планёр спорты.* || *с. мәгъ.* Шундый аппаратны очырту өчен билгеләнгән. *Планёр станциясе.*

ПЛАНЕРИЗМ *и.* Планёрда оча сәнгате; планёр спорты белән шөгыльләнү эше.

ПЛАНЁРКА *и. сөйл.* Агымдагы эш планын тикшерүгә багышланган кыска гына производство киңәшмәсе. *Резервуарны тәмамлый алмыйлар дип тагын планёркада сүз булачак.* А. Гыйләҗев. *Ниләр генә эшләп карамады директор! Сәгать саен летучкалар җыйды, планёркалар уздырды.* В. Монасыйпов.

ПЛАНЕРЛАУ *ф.* Моторы сүндерелгән очкычта яки планёрда әкренләп, салмак кына жиргә төшү.

ПЛАНЕРОДРОМ *и.* Планёрлар һавага күтәрелә һәм төшә торган мәйданчык.

ПЛАНЁРЧЫ *и.* Планёрда очучы. *Планёрчылар ярышында беренче урынны алачагына [Ибраһим] ышана иде.* Жиңү юлы.

ПЛАНЕТ *и.* Яшелчә культураларының рәт араларын эшкәртә торган культиватор. *Атлы планет. Кул планеты.*

ПЛАНЕ'ТА *и.* Кояш тирәсендә әйләнә һәм аннан яктылык алып ялтырап күренә торган күк жисеме. *Зур планеталар.* □ [*Кояш*] *Жир, Меркурий, Плутон һ. б. планеталардан 750 тапкыр авыррак.* Г. Гобәй. *Безнең Галактика системасында кимендә 100 меңләп Җиргә охшашлы планета булырга тиеш.* А. Тимергалин. || *кит.* Жир шары. *Без искене жимереп, планетада Тигез тормыш, матур, яңаны Төзү уе белән янабыз!* Һ. Такташ. *Язы булыр ул көн бөтен планетаның: Коллык, изелү газапларын онытып шунда, Вәкилләре барлык азат халыкларның Бәйрәм итәр башкалабыз уртасында.* Ә. Исхак.

ПЛАНЕТААРА *с.* 1. Планеталар арасында хәрәкәт итә торган. *Планетаара автомат станция.* || Планеталар арасында була торган. *Планетаара сәяхәт вакытында кеше бер үк айны, елны, берничә елны икешәр мәртәбә яшәргә мөмкин.* Р. Мостафин.

2. Планеталар арасында булган. *Планетаара бушлык. Планетаара киңлек.*

ПЛАНЕТАР: планетар томанлыклар *астр.*— үзәгендә бик югары температуралы йолдыз булган һәм планеталарның дискына (түгәрәгенә) охшаш томанлы якты таптай күренгән сирәк газ тупланышы.

ПЛАНЕТА'РИЙ *и.* 1. Гөмбәз сыман экранда планеталар һәм башка күк җисемнәренең хәрәкәтен күрсәтә торган прибор.

2. Шул прибор ярдәмендә планеталар һәм башка күк җисемнәренең урыннарын һәм хәрәкәтләрен тамашачыларга күрсәтә торган бина. *Менә планетарий балкып [тора].* Г. Кашшаф.

ПЛАНЕТО'ЛОГ *и.* Планеталарны өйрәнүче астроном.

ПЛАНИМЕТР *и.* Сызымдагы йомык фигураларның мәйданын үлчәү приборы.

ПЛАНИМЕ'ТРИЯ *и.* Элементар геометриянең бер яссылыкта урнашкан фигураларның үзлекләрен өйрәнә торган бүлеге.

ПЛАНИРО'ВКА *и.* Берәр бөтен нәрсәдә аерым кисәкләрнең үзара урнашуы, үзара торышы; берәр корылманың эчке төзелеше. *Бинаның тышкы күренешенә үзгәрешләр кертергә ярый, әмма эчке планировкасына кул тидерергә рөхсәт ителми иде.* М. Маликова.

ПЛАНИСФЕ'РА *и. астр.* Җирне яки күк йөзен ярымшарлар формасында сурәтли торган карта. *Күк планисферасы.*

ПЛА'НКА *и. сөйл.* Юка, тар шома такта яки металл пластинка. [*Александр*] *үлчәүгә һәм кешенең буен үлчи торган планкага карап алды.* Г. Әпсәләмов. *Аның башы әкрен генә уң якка, гармун планкаларының дүрт сәдәбе өстенә иелеп төшә.* Ш. Маннур.

ПЛАНКТОН *и. биол.* Диңгез, елга, күл суының бөтен тирәнлегендә яшәп, су агымы белән хәрәкәт итә торган вак үсемлек һәм хайван организмнары җыелмасы. *Балыкларның азык базасы вак кына организмнардан — суда йөзеп тереклек итүче планктоннардан [тора].* Сов. әд. *Су агымы алып килгән планктонны суыручы гигант кабырчыклар очраштыргалый.* М. Юныс.

ПЛАНЛАШТЫРУ *ф.* 1. Берәр эш яки чараның тәртибен билгеләү, планын төзү.— *Берәр хикәя кебек нәрсәне язар алдыннан, мин, иң әлек үземнең күз алдымнан үткән вакыйгалардан, фактлардан чыгып, шул язачак нәрсәмнең эчтәлеген планлаштырам.* З. Бәширн.— *Дәдәгез, быелга да шул мөмкинлекләрдән чыгып планлаштырыйк.* Ә. Маликов.

2. Берәр нәрсә яки эш эшләргә ниятләү, исәпләү. *Хәдичә, иртәдән театрга баруны планлаштырган булса да, бу ниятне шатланып үзгәртте.* А. Расих. [*Мин*] *„Тукай иҗатында ода жанры һәм татар совет әдәбиятында аның традицияcе" дигән темага мәкалә бирергә планлаштырам.* М. Гайнуллин.

ПЛАНЛЫ *с.* Алдан төзелгән план буенча тормышка ашырыла яки алып барыла торган. *Планлы хуҗалык.* □ *Терлекләрнең нәселләрен яхшыртуны планлы рәвештә алып барырга кирәк.* Ә. Еники. || *рәв. мәгъ.* Алдан төзелгән план буенча.— *Крестьяннарның колхозга берләшүе хуҗалыкны планлы идарә итәргә мөмкинлек бирәчәк.* Ш. Рәкыйпов. [*Театр*] *бөтен репертуар, спектакльләргә кабул итү эшләрен планлы алып барырга тиеш.* М. Җәлил.

ПЛАНЛЫЛЫК *и.* Планлы булу; эшне план нигезендә алып бару. *Тематик план --- театрның репертуарына планлылык кертәчәк.* М. Җәлил.

ПЛАНОВИК *и.* Производство планнарын төзү белән шөгыльләнүче белгеч.

ПЛАНТАЖ *и. а.-х.* Җимеш агачларын утырту алдыннан җирне тирән итеп казып чыгу. || *с. мәгъ.* Шундый эш өчен махсус (инвентарь турында). *Плантаж сабаны.*

ПЛАНТАЖЛАП: плантажлап сөрү *а.-х.*—туфракны тирән эшкәртеп, плантаж сабаны белән сөрү.

ПЛАНТА'ТОР *и.* Плантация хуҗасы. *Джон Браун— --- колбиләүче плантаторларга каршы негрлар восстаниесен башлаган герой.* Ш. Мөдәррис. *Плантаторлар октябрьдан ноябрьга кадәр авылга кайта алмыйлар.* Шура.

ПЛАНТА'ТОРЛЫК *и.* Плантатор булу.

ПЛАНТА'ЦИЯ *и.* 1. Шикәр камышы, дөге, кофе һ. б. ш. культураларны игү белән шөгыльләнә торган эре капиталистик җир биләү хуҗалыгы.

2. Махсус авыл хуҗалыгы культурасы чәчелгән җир мәйданы. *Күксагыз плантациясе. Чәй плантациясе.* □ *Җидееллыкның беренче язында үк җиң сызганып, бил бөгеп шикәр чөгендере плантациясендә эшләргә булдык.* Г. Галиев. *Кабина тәрәзәсеннән мәшһүр „Абрау-Дюрсу" совхозының виноград плантацияләрен күзәтеп барам.* Г. Минский.

ПЛАНШЕТ *и.* 1. *махс.* Берәр урынны топографик планга төшергәндә кулланыла торган, кәгазь ябыштырылган дүрткырлы шома такта. *Ишек алдына җыелган күл-күл сулар аркылы сикергәләп, планшет тоткан бер егет узды.* Г. Ахунов.

2. *махс.* Геодезик план, сызым. *Диңгез төбенең җентекле планшетын төзү.*

3. Карталар салып йөртү өчен бер ягы үтә күренмәле материалдан эшләнгән яссы сумка. *Журавлёв планшетыннан сугыш картасы чыгара.* Ә. Фәйзи. *Баймурзин, планшетындагы картага карап, ялгыш очучыга задание бирә башлады.* С. Баттал.

ПЛАНШИР *и. махс.* Көймәләрнең, корабларның бортына яки палуба кырыена бәрелүдән саклау өчен куела торган калын борыс.

ПЛА'СТИК *с.* 1. Барлык өлешләре дә бер-беренә ярашып, килешеп тора торган, нәфис. *Пластик статуя.*

2. Салмак, нәфис, зифа (хәрәкәт, ишарә һ. б. ш. турында). || *күч.* Тәэсирле, нәфис, салмак. *Нури Арсланов --- әсәрләре сюжетлы, пластик.* С. Хәким. *Пластик сизүчәнлек [Леонардо да Винчының] игътибар үзәгендә тора.* Сов. әд.

3. *физ.* Кыскач, бөккәч теләсә нинди формага керә һәм шул форманы саклый ала торган. *Пластик металл. Пластик матдә.*

4. *мед.* Пешкән яки җәрәхәтләнгән урынга тире яисә тире асты тукымасын күчерү белән бәйләнгән. *Пластик операция. Пластик хирургия.*

5. *и. мәгъ.* Пластик масса. [*Корабның*] *эчке стеналары сөт төсле ялтыравык пластиктан ясалган.* Р. Мостафин. *Бер автоһәвәскәр, --- металл урынына пыялалы пластик кулланып, машинасын нык кына җиңеләйткән.* А. Тимергалин.

Пластик масса — җылытканда теләсә нинди калыпка җиңел салына һәм соңыннан шул формасын югалтмый торган табигый яки ясалма материал; пластмасса. *Безнең хөкүмәтебез пластик массалар җитештерүне көчәйтү турында махсус карар кабул итте.* А. Расих.

ПЛА'СТИКА *и. сәнг.* 1. Сынлы сәнгать, скульптура. *Пластика мәктәбе.*

2. Сынның һ. б. ш. әйберләрнең нәфислеге, зифалыгы, бөтен яктан килешкәнлеге. [*Бу портретта*]

баш белән күкрәк арасындагы бәйләнеш пластикасы [*юк*]. Сов. әд.

3. Тән хәрәкәтләрен сыгылмалы, ритмлы, нәфис итү сәнгате.— [*Сезгә*] *пластика, матур сүз, декламация, грим салу дәресләре бирерләр.* Т. Гыйззәт.

ПЛАСТИКАТ *и.* Пластик массаның бер төре.

ПЛАСТИКЛЫК *и.* 1. Пластик (1—2 мәгъ.) булу; сыгылмалылык. [*Тукайның*] *шигъри телендә сүзләрнең --- шигъри сыгылмалылыгы (пластиклыгы) ачылды.* Г. Халит.

2. *физ.* Матдәләрнең теләсә нинди формага кереп, шул форманы тышкы көч тәэсире туктаганнан соң да саклау үзлеге.

ПЛАСТИЛИН *и.* Балавыз, балчык, тальк, күкерт һәм май катнашмасыннан гыйбарәт кипми торган йомшак пластик масса. *Киштәгә гипс, мәрмәр, агач һәм пластилиннан ясалган эреле-ваклы фигуралар, бюстлар тезелгән.* М. Маликова. || *с. мәгъ.* Шундый массадан ясалган. *Бакый абыйның мастерскоенда --- нинди генә пластилин фигуралар юк.* Г. Кашшаф.

ПЛАСТИ'НКА *и.* 1. Өсте шомартылган бик юка металл, резин яки агач тактачык. *Корыч пластинка.* □ — *Катушканың пластинкалары юкарган, чыдатмаячаклар.* Г. Ахунов.

2. Тавыш (сөйләм, җыр, музыка) язылган патефон яки граммофон тәлинкәсе. *Кариев тавышы язып алынган пластинка үз архивымда саклана.* Х. Сәлимҗанов. *Кулга эләккән беренче пластинканы куеп, патефонны борып җибәрдем.* И. Гази.

3. Фотографиядә: яктылык сизә торган эмульсияле пыяла.

◇ **Пластинканы алмаштыру (әйләндерү)** — 1) бер темага сөйләүдән туктап, башка нәрсә турында сөйли башлау. *Мәрьям дәшмәде. Газизне шул рәвешле юкка чыгарып ташлагач, Шәүкәт „пластинканы әйләндерде".* М. Маликова; 2) сөйләгәндә тавышны яки берәр нәрсәгә, кешегә мөнәсәбәтне үзгәртү. *Мин дә әрсезләндем һәм „пластинканы алмаштырып" сөйләшә башладым: „Чәпчемә, Хәмидулла абзый".* Б. Камалов.

ПЛАСТИ'НКАЛЫ *с.* 1. Пластинкасы (1—2 мәгъ.) булган, пластинка белән тәэмин ителгән.

2. Пластинка (3 мәгъ.) ярдәмендә эшли торган. *Пластинкалы фотоаппарат.*

ПЛАСТМАСС *с.* Пластмассадан ясалган. *Пластмасс стеллажларга җәелгән бу чуерташлар арасында үсемлекләр ничек тукланалар?* Г. Галиев. *Кара пластмасс ярты чәч тарагының ике ягына да Мусаның Казан һәм Мәскәү адреслары язылган.* Г. Кашшаф.

ПЛАСТМА'ССА *и.* Пластик масса. *Пластмассадан ясалган тешле тәгәрмәчләр тавышсыз эшлиләр.* Г. Камай. *Ул чакларда электр җиһазлары һәртөрле юка калайлардан эшләнгән булса, хәзер алар пластмассалардан ясалган.* Г. Галиев. || *с. мәгъ.* Шундый матдәдән ясалган. *Пластмасса әйберләр.* □ [*Кыз*] *нечкә биленә ак пластмасса каеш буып куйган.* Н. Фәттах. *Гардеробтагы карт --- тун белән бүрекне алып элде дә Зөлфәгә ак пластмасса номер бирде.* М. Маликова.

ПЛАСТУН *и. тар.* Кубань казакларының разведка һәм каравыл хезмәтен үти торган махсус пехота отрядында сугышчы. *Ирекле татар укчылары батальоны --- пластуннар бригадасындагы Питрюк полкына килеп кушылды.* М. Садри.

ПЛАСТУ'НЧА *рәв.* Гәүдәне җирдән аермыйча, терсәкләргә таянып (шуышу турында). *Барыбыз да сузылып яттык та, пластунча, бик саклык белән, алга шуыша башладык.* Ә. Айдар. [*Панкратов*] *пластунча шуышканда да җиргә сыенырак бара.* Г. Әпсәләмов.

ПЛАСТУНЧЫ *и.* Гәүдәне җирдән аермыйча терсәкләргә таянып кына шуышучы солдат. [*Опанас*], *түмгәктән-түмгәккә ышыклана-ышыклана, шуышып китте. Ротада ул иң оста пластунчы иде.* Г. Әпсәләмов.

ПЛА'СТЫРЬ *и.* 1. Яралы яки үлекләгән һ. б. ш. урыннарга ябу өчен тукыма кисәгенә сыланган ябышкак дару. *Борынындагы кутырына пластырь ябыштырган байбәтчә кызлар алдында җитезлеген күрсәтергә теләде.* К. Тинчурин. *Икенче* [*солдатның*] *җилкәсенә куш чуан чыгып килә иде, --- пластырь салдык.* М. Рафиков.

2. Көймә, кораб һ. б. ш. ның тишелгән урыннарын вакытлыча каплый торган тыгыз парусин (калын киндер) җайланма.

ПЛАТАН *и. бот.* Киң, җәенке яфраклы һәм яшькелт-соры кайрылы бик зур агач; чинар. *Муса, машинадан чыгу белән үк, каршында өч биек платан агачы күрде.* Ш. Маннур.— *Платаннар янында төшкән рәсемеңне күрдем.* Р. Гатауллин.

ПЛА'ТИНА *и. к.* ак алтын (1 мәгъ.). [*Сөләйман*] *көлгәндә --- тоташ платинадан эшләнгән теш казналарын күрсәтергә тырышучы атаклы Шәриповны* [*таныды*]. К. Тинчурин.

ПЛА'ТИНАЛАУ *ф. тех.* Төрле химик тәэсирләрдән саклау өчен металл әйбер өстенә платина йөгертү, шул әйбернең өстен платина белән каплау.

ПЛАТИНИТ *и. хим.* Тимер һәм никель кушылган эретмә (вакуум аппаратлары һәм кыздырма электр лампалары ясау өчен кулланыла).

ПЛАТО *и. геогр.* Биек булмаган яссы таулык; тау өстендәге киң тигез җир. *Без Көнчыгыш Карпат аша үтеп чыгып, Трансильвания платосына төшәргә --- тиеш идек.* Г. Сафиуллин.

ПЛАТОНИЗМ *и.* 1. Борынгы грек философы Платон һәм аның тәгълиматын дәвам иттерүчеләрнең идеалистик философиясе.

2. *кит.* Дәртлелекнең, хиснең бернинди катнашы булмаучылык (мәхәббәт, кызыксыну һ. б. ш. турында).

ПЛАТО'НИК *с. кит.* Бертөрле дә хис, дәрт катнашмаган. *Платоник мәхәббәт.*

ПЛАТФО'РМА *и.* 1. Яссы ташлардан, цементтан биек итеп ясалган тигез мәйданчык. || Поезд туктый торган урында тимер юл полотносы буена ясалган шундый мәйданчык. *Искереп беткән паровоз, артына таккан унбишләп теплушканы өстерәп, станциянең платформасы алдына китереп туктатты.* Ш. Усманов. *„Поезд килә!" дигән сүзләр ишетелде, халык һәммәсе вокзалның тышкы ягына, платформага чыкты.* Ш. Мөхәммәдев. || Кечерәк тимер юл станциясе. *„Аракчино" ачык платформасы.*

2. Кырыйлары, бөртлары ярты метр биеклегендәге түбәсез товар вагоны. *Паровоз өченче платформаны— озын, юан кара чыршы кәүсәсе кадәр көпшәле, кеше кереп ятарлык киң авызлы пушка урнашкан платформаны — тартып алды.* Г. Гобәй. *Носов госпиталь өчен бирелгән платформага иң кирәкле әйберләрне генә төяргә куштым.* А. Хәсәнов.

3. *күч.* Берәр политик партиянең, төркемнең карашлары, политик таләпләре системасы, эш итү программасы. *М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал һәм башкалар, турыдан-туры Советлар власте платформасына басып, социализм төзелешенең актив эшчеләре булып киттеләр.* М. Җәлил. [*Ул*] *меньшевик-эсерлар платформасына тарта иде.* Ш. Камал.

◇ **Платформада тору** — билгеле бер карашларны яки партия интересларын яклау. *Уң кадетлар платформасында торган бу „Мөселман иттифакы" партиясе 1905 елгы революция чорында турыдан-туры реакцион роль уйнады.* М. Җәлил.— *Профсоюз дискуссиясендә кайсы платформада тордың? — Ленин платформасында.* Каз. утл.

ПЛАУН *и. бот.* Сабаклары җиргә яки суга ятып тора торган, споралы, абага сыман үсемлек, су мүге; бүре аягы; ликоподий. *Чукмар сыман плаун. Яньчек плаун.*

ПЛАФОН *и.* 1. Рәсемнәр, төрле бизәкләр төшерелгән түшәм. || Түшәмгә төшерелгән, ябыштырылган рәсемнәр, бизәкләр. *Мәскәү метросының „Киев" станциясендәге плафоннар.*

2. Электр лампалары өчен ярым тоник ярымшар рәвешле абажур. *Ул арада, аксыл плафоннарда ут сүнеп, кызыл авария лампалары кабынды.* А. Тимергалин. *Тамаша залы куе зәңгәр түшәмдәге сөт төсле плафоннарга тезелгән сирәк лампочкалар белән генә яктыртылган.* М. Маликова.

ПЛАЦ *и. хәрби.* Хәрби парадлар һәм өйрәнүләр үткәрелә торган мәйдан.— *Плацка тезелергә! — дип акырыша башлады сакчылар.* Каз. утл.

ПЛАЦДАРМ *и.* Сугыш хәрәкәтләре яки хәрби һөҗүмгә хәзерлек эшләре алып барыла торган урын. *Пехота батальоны иркенләп елганы кичә һәм, сул як ярда плацдарм яулап алып, нык ыгый.* Г. Иделле. *Менә безнең артта бер тотам җир кисәге — безнең плацдарм! Безнең яшәү мәйданыбыз!* Х. Госман. || Күрше илгә һөҗүм итәр өчен гаскәр тупларлык җир.

ПЛАЦКАРТ *и.* 1. Тимер юл вагонында билгеле бер урын алыр өчен махсус хак белән билетка өстәп бирелә торган квитанция. *Килүче-китүче, баручы-кайтучылар, күченүчеләр күп булганлыктан, вагон тыгыз иде. Шуңа күрә Исхак плацкарт ала алмады. Аңа тар гына урынга кысылып утырырга туры килде.* С. Рафиков.

2. *с. мәгъ.* Шундый квитанциясе булган. *Плацкарт билет.* || Шундый квитанция, шундый билет хакына пассажирга тәкъдим ителә торган. *Плацкарт вагон. Плацкарт урын.*

ПЛАШКИ *и. иск.* Бәйрәмнәрдә багана башына куелган сай савытларга керосин салып кичен ут ягу; гомумән, шундый ут ягылган бәйрәм кичәсе. *Дәхи бардыр Казанда бер плашки, Гафил булма бу көннәрне сорашмый, Флаг белән беленер көннәрендә, Урамга ут ягылыр төннәрендә.* Җ. Вәлиди.

◇ **Плашкига чыгу** *иск.* — урамда кичен кәеф-сафа сөреп йөрү, бигрәк тә хатын-кыз артыннан йөрү. — *Җизнилләр әле алар үткән атнаны плашкига да чыктылар.* Г. Камал.

ПЛАШКО'УТ *и. махс.* Порт эчендә бер урыннан икенче урынга йөк ташу, күпер салу өчен файдаланыла торган палубасыз, яссы төпле зур судно. || *с. мәгъ.* Шундый суднолардан төзелгән. *Плашкоут күпер.*

ПЛАЩ *и.* 1. Җилкәгә салына торган җиңсез, киң өске кием. [*Гарәп*] *чуар чалмадан, башмактан, өстенә кара җиңсез чапан — плащ япкан.* Ф. Бурнаш. *Плащка төренгән, башына зур читле кара эшләпә кигән Салих килә.* Ф. Әмирхан.

2. Су үткәрми торган пальто. *Яңгыр булса-нитсә дип, башлыклы плащ киеп утырган ике юлчының берсе тарантасның сул ягына сикереп төште дә плащ төймәләрен чишеп җибәрде.* И. Гази. *Хәбибуллин брезент плащын һәм пиджагын салып ишек яңагындагы чөйгә элә.* Ә. Еники.

ПЛАЩЛЫК *с.* Плащ өчен яраклы, плащ тегә торган. *Плащлык тукыма.* || Плащка җитәрлек.

ПЛАЩ-ПАЛА'ТКА *и.* Кирәк вакытта плащ та, палатка да булып хезмәт итә торган су үткәрмәс җилән. *Күзәтү һәм сак булу турында боерыклар биргәч, [Сөләйманов] плащ-палаткага төренде дә, бөрешеп, агач төбенә ятты.* И. Гази. *Агачлар уртасында плащ-палаткалардан ясалган чатырлар тезелеп киткән.* Ә. Айдар.

ПЛЕБЕЙ *и.* 1. *тар.* Борынгы Римда: ирекле, әмма элек һичбер төрле политик хокукка ия булмаган иң түбән иҗтимагый катлау вәкиле.

2. Буржуа-дворян катлавы телендә: дворян нәселеннән булмаган, түбән катлау кешесе, кара халык. *Ул, янәсе — аристократ әдип, Без, янәсе, — люмпен, плебей!..* Х. Туфан.— *Миңа ике көн туенырлык акча кирәк икән, минем ише плебей аны пристаньда ярты көн йөк бушатып табарга тиешле.* Э. Касыймов. || *с. мәгъ.* Шундый кешегә хас. *Плебей чырайлы ямьсез бер казак офицеры [күренә].* Ф. Хөсни.

ПЛЕБЕЙЛЫК *и.* 1. Чыгышы ягыннан плебей булу. 2. *күч. иск.* Үз-үзен плебейларча тупас тоту.

ПЛЕБИСЦИТ *и. кит.* Гомумдәүләт күләмендә әһәмияткә ия булган мәсьәләгә карата бөтен халыкның тавыш бирүе; референдум. *Яңа конституцияне плебисцитка кую.*

ПЛЕ'ВРА *и. анат.* Күкрәк читлеге стеналарын һәм үпкәләрне каплаган яры; үпкә пәрдәсе. *Плевра төкчәләре.*

ПЛЕВРАЛЬ *с.* Плеврага бәйләнешле. *Плевраль яры.*

ПЛЕВРИТ *и.* Үпкә ярысы шешү, үпкә пәрдәсе ялкынсыну.— *Мин плеврит белән авырып киттем.* Г. Газиз.

ПЛЕД *и.* Чачаклы калын йон шәл. *Рәшидә пледын бөркәнеп чыга.* Ә. Фәйзи.

ПЛЕЗИОЗАВР *и.* Борынгы чорда диңгездә яшәгән, хәзер казылмаларда гына табыла торган озын муенлы, кечкенә башлы, ишкәгаяклы бик зур кәлтә. [*Үрмәлүчеләрнең*] *кайберләре диңгез ерткычларына, ихтиозаврга, плезиозаврга әйләнгән. Беренче кәлтә еланнар бу чорда имезүче хайваннар рәтенә керә башлаганнар.* А. Фаткуллин.

ПЛЕКСИГЛАС *и.* Үтә күренмәле пластмасса; органик пыяла. [*Чалдаев*] *медицинада беренче булып баш сөягенең ватык урынына кую өчен плексиглас кулланды.* Г. Әпсәләмов. *Гади пыяланы пластмассадан эшләнгән органик пыяла (плексиглас) белән чагыштырып та булмый.* Азат хатын. || *с. мәгъ.* Шундый пластмассадан ясалган. *Плексиглас тартма. Плексиглас тәрәзә.*

ПЛЕН *и. сөйл.* Әсирлек. *Коралларын ташлап, кул күтәрергә өлгергән немец солдатлары пленга алыналар.* Г. Кутуй.— *Җәгъфәрев иптәш акларга пленга эләккән иде, аны шунда ук каты газаплап үтергәннәр.* А. Шамов.

Плен алу (төшерү) *сөйл.*— сугыш вакытында әсир итү. *Аклар менә нәрсәләр язалар: „Төньяк Тавриядә генерал Слащев частьлары кызылларның өч мең җәяүлесен плен алды".* Г. Бәширов. *Ул да түгел, Хәлимне плен төшереп, „атарга" алып киттеләр.* И. Гази. **Плен төшү** — сугыш вакытында дошман кулына әсирлеккә эләгү, әсирлеккә төшү. *Немецлар плен төшкән кешеләр турында халыкара изге саналган кагыйдәләр белән исәпләшеп тә карамыйлар.* Х. Мөҗәй.

ПЛЕНАР *с.* Сайланып куелган, җитәкче органның, конференциянең, сессиянең һ. б. барлык членнары катнашында үткәрелә торган. *Кызганычка каршы, бу вакытта пленар утырышның тәнәфесе иде.* Каз. утл.

ПЛЁНКА *и.* 1. Бер ягына яктылык тәэсир итә торган катлау сыланган һәм фотога, кинога төшерүдә кулланыла торган үтә күренмәле эластик тасма. [*Илһам*] *икенче килгәндә чәкәнбашлардагы орлыкларның сап-сары сырга булып әверелүен, өченче килгәндә яфракларның саргая башлавын - - - плёнкага төшереп алды.* Г. Галиев.— *Советлар Союзында чыга торган фильмнарның яртысы шушы фабрика плёнкаларында басыла.* Г. Ахунов.

2. Бер ягына тавыш языла торган катлау сыланган магнитофон тасмасы.

ПЛЁНКАЛЫ: плёнкалы фотоаппарат — плёнкага (1 мәгъ.) төшерә торган фотоаппарат.

ПЛЕ'НУМ *и.* Пленар утырыш. *Василий Петрович - - - кичә Мәскәүгә, Үзәк Контроль Комиссиясе пленумына китте.* Г. Ибраһимов. *Шушы [1933] елның февраль ае урталарында Совет язучылары союзын оештыру комитетының икенче пленумы булып үтте.* М. Җәлил.

ПЛЕОНАЗМ *и. әд.* Мәгънәләре белән бер-берләренә якын яки бер-берләрен кабатлаучы сүзләрдән торган әйләнмә (мәсәлән: *үз күзләрем белән күрдем, карт ветеран).*

ПЛЕЯ'ДА *и.* Бер үк чорда, бер үк өлкәдә дан казанган күренекле эшлеклеләр төркеме. *Татар театрында исемнәре милли культурабыз тарихына алтын хәрефләр белән язылырлык артистлар плеядасы эшләгән һәм эшли.* Х. Кумысников. *Бөек Гомердан алып дөнья классикасы меңнәрчә дәһи шагыйрьләрне белә. Муса шул данлы плеядага үз авазы, үз музыкасы белән килеп керә.* Г. Кашшаф.

ПЛИ *ы. хәрби.* Ата башларга бирелгән боерык (хәзер кулланылмый). *Әнвәр „пли" дип команда бирде. Мылтыклар бер ноктага карап аттылар.* К. Нәҗми. *— Айт-два, һоп! Пли! Агач винтовкадан булдырып була булуын, менә чыны белән атып карыйсы иде!* Р. Ишморат.

ПЛИ'НТУС *и. махс.* 1. Стена белән идән арасындагы ярыкны каплый торган тар гына такта.

2. Мичнең, стенаның бераз чыгып тора торган аскы өлеше; шулай ук колоннаның, багананың [яссы, дүрткырлы нигезе.

ПЛИОЦЕН *и. махс.* Җир тарихында өченчел периодның соңгы чоры. [*Профессор*] *таш кисәге белән бергә үзе дә туп-туры плиоценга* [*кучкән*] *булыр иде.* Каз. утл.

ПЛИС *и. иск.* Киже-мамыктан тукылган һәм бәрхеткә охшашлы төкле тукыма; киже-мамык бәрхет. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. [*Карт*] *кызыл күлмәк, плис чалбар кигән - - - кучерны күрде.* Ш. Мөхәммәдев.

ПЛИССЕ' *и.* Материядә махсус бөреп яки үтүк белән бастырып ясалган вак сырлар.

ПЛИССЕЛЫ *с.* Плиссесы (сырлары) булган, плиссе ясап (сырлап) тегелгән. *Плисселы итәк.*

ПЛИТА *и.* 1. Зур, тигез, яссы таш яки металл такта.— *Төзелешне тапшырганда, СУ-6 дан шактый гына стандартсыз тимер-бетон плиталар калган.* А. Гыйләҗев. *Аста басып торучы ике кеше* [*кран*] *ыргагына тимер-бетон плитаны корыч аркан белән эләктереп куйды.* Г. Ахунов.

2. Чәй кайнату, ашамлык пешерү өчен түгәрәк тишекле юка тимер кисәге һәм шул тимер кисәге капланган кечерәк мич. *Өй җылы, плитада чәй кайнап тора...* Ш. Камал. *Хәлим, повар кушканнарны үтәп, плита тирәсендә ыгы-зыгы килеп йөри башлады.* Г. Гобәй.

ПЛИ'ТКА *и.* 1. Дүрткырлы кечкенә яссы кисәк. *Кесәмдә ярты плитка шоколад бар иде.* Ә. Айдар.

2. Кечерәк плита (2 мәгъ.); шулай ук электр плитасы.

ПЛИ'ТКАЛЫ *с.* Плиткалар рәвешендә эшләнгән. *Плиткалы чәй. Плиткалы шоколад.*

ПЛИТӘ *и. сөйл. к.* плита. *Плитә өстенә җылынырга су утырттым.* Н. Фәттах. *Таш плитә җәелгән идән аяк атлаган саен шак-шок килеп, яңгырап кала.* Каз. утл.

ПЛО'МБА *и.* 1. Бикләнгән ишекләргә, төрелгән товарларга тагыла торган, мөһер яисә келәймә сугылган кургашын, сургыч һ. б. ш. пластик матдә кисәге (аны ватмыйча, җебен өзмичә товарны, ишекне ачып булмый). *Кладовойларын үз пломбасы илә пичәтләттем.* Ш. Мөхәммәдев.—*Кинобудкага пломба салмакчылар иде, тамашачылар гауга күтәрделәр.* М. Хәсәнов.

2. Бозык тештәге куышлыкны ямый торган каты матдә.

ПЛО'МБАЛАУ *ф.* 1. Товарга, ишеккә пломба (1 мәгъ.) тагу, пломба сугу. *Пионерлар тимер юл эшчесенең вагон ишекләрен җеп шикелле генә тимер чыбык белән пломбалап китеп барганын күр*[*деләр*]. Г. Гобәй.— [*Бүлмәне*] *бүген үк пломбалагыз!* М. Хәсәнов.

2. Тешкә пломба (2 мәгъ.) салу, теш куышлыгын пломба белән ямау.

ПЛОМБИР I *и.* Сөт өстенә җимеш, сок һ. б. ш. нәрсә кушып ясалган мороженое.

ПЛОМБИР II *и.* Товарга, ишеккә пломба сала торган келәшчә сыман кыскыч.

ПЛОТИ'НА *и.* Су агымын туктатып ясалма сусаклагыч булдыру һәм электр энергиясе алу өчен төзелгән корылма; буа. *Шлюзлы плотина. Бетон плотина. Плотина кору.* □ *— 300—400 метрлык канау казып, суның биеклеген өч-дүрт метрга күтәргәндә, сезнең үз җирегездә менә дигән плотина эшләп булачак.* Г. Әпсәләмов.— *Сыр-Дәрья плотиналарын ачып, бөтен даланы су белән тутырырбыз.* Ш. Усманов.

ПЛОЩА'ДКА *и.* 1. Ике баскыч арасындагы тигез мәйданчык.

2. Вагонның кешеләр керә һәм чыга торган алгы яки арткы өлеше. *Трамвайда кеше күп иде, тыгын иде. Ул алдагы тукталышта төшеп калырга уйлады. Ләкин шунда площадканың бер почмагында, тәрәзә буенда, сөйләшеп торучы егет белән кызны күреп төшми калды.* Г. Ахунов. *Менә шушы нотыкны ул вокзалда, икенче звонок булгач, үзен озатырга төшкән халыкка карап, вагон площадкасыннан сөйләргә ният иткән иде.* Ш. Камал.

ПЛУГАРЬ *и. сөйл.* Трактор сабаның карап (күтәреп, төшереп) йөртүче кеше.—*Миңа әнә плугарьлар кирәк, чәчүчеләр кирәк.* Р. Төхфәтуллин.—*Ул трактордa плугарь булып эшләде.* Н. Фәттах.

ПЛУГАРЬЛЫК *и. сөйл.* Плугарь булу, плугарь хезмәте. *Плугарьлыкта йөрү.*

ПЛУТОКРАТ *и. кит.* Хаким сыйныфның иң бай катлавыннан чыккан һәм үз байлыгы аркасында власть һәм йогынты көченә ия булган кеше.

ПЛУТОКРА'ТИК *с. кит.* Плутократиягә хас. *Плутократик режим.*

ПЛУТОКРА'ТИЯ *и. кит.* 1. Халык тулысынча хокуксыз булып, югары катлауның иң бай төркеме генә дәүләт белән идарә итә торган политик строй. *Мин Англия-Америка плутократиясен фаш итә торган материаллар туплый идем.* Г. Кашшаф.

2. *җый.* Плутократлар.

ПЛУТО'НИЙ *и. хим.* Радиоактив үзлекләре булган ясалма химик элемент.

ПЛЮРАЛЬ: плюраль вотум — кайбер буржуаз илләрнең законнарында: милек яки белем цензына (дәрәҗәсенә) карап, бер сайлаучы берничә тавыш бирү хокукына ия булу.

ПЛЮС *и.* 1. *мат.* Зурлыкның уңай булуын яки кушу гамәлен белдерә торган билге (+).

2. Ике сан арасында куелып, икенчесенең беренчесенә кушылуын белдерә. *Ике плюс ике.*

3. *мат.* Уңай зурлык. || Температураның нульдән югары булуын күрсәтү өчен кулланыла. *Тышта +20° җылы.* □ *Январь аенда да* [*Кырымда*] *температура плюс була икән.* Г. Иделле.

4. *күч. сөйл.* Яхшы, уңай як, өстенлек.— *Моны аңлавың үзе бер плюс. Димәк, сине сайлап дөрес иткәнбез.* М. Хәсәнов.— *Без барыбыз да заман*

продукциясе. Үзебездә заманның плюсларын һәм минусларын йөртәбез. Г. Ахунов.

5. Мәктәп практикасында укучының белеме яки үзүзен тотышы теге яки бу баллдан бераз югары булуын күрсәтә торган билге. *Плюс дүртле.*

6. *күч. сөйл.* Өстәвенә, шуның өстенә.— *Синең алдыңда хәзер ике юл тора: берсе — пар ат җигелгән ялтыравык коляскага утырып, карт хажи белән китәргә. Плюс аның ярты дәүләте.* Ш. Камал.

ПЛЮШ *и.* Уң ягы бәрхетнекеннән озынрак һәм сирәгрәк йомшак йончалы тукыма.— *Ишек чаршавы өчен яхшы плюш алып кайтсаң, бик һәйбәт булыр иде.* Г. Камал. [*Тәрәзә*] *пәрдәләре дә шул ук төстәге плюштан ясалган.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, ясалган.—*Сиңа бик һәйбәт плюш тышлы кесәбикә ниятләдек.* К. Нәҗми. [*Апа*] *өстенә плюш жикет кигән.* Г. Ахунов. || Шундый тукыма белән тышланган. *Яңа, ыспай немец формасы кигән Иванов оятсыз рәвештә плюш диванга җәелеп утырган.* Каз. утл.

ПЛЯЖ *и.* Су коену яки кояшта кызыну өчен комлы сөзәк яр буе. *Син басарсың ярга. Кызу нурлар Пляждагы комны җылытырлар.* Ә. Ерикәй. || *с. мәгъ.* Шунда кию өчен махсус тегелгән. *Су коену өчен пляж костюмнары ки[дек].* С. Сөләйманова.

ПНЕВМА'ТИК *с. махс.* Кысылган (зур басымлы) һава яки пар ярдәмендә эшли торган. *Пневматик мылтык. Пневматик насос. Пневматик тормоз.* □ *Ул пневматик аппарат себеркесез-чүпрәксез генә бөтен квартираны җыештыра.* А. Тимергалин. *Югарыда да, түбәндә дә металл чыңы, пневматик чүкечләр тырылдавы, мотор жулавы һәм тагын мең төрле тавышлар ишетелә башлады.* А. Расих.

ПНЕВМА'ТИКА *и. махс.* Кысылган һава яки пар ярдәмендә эшли, хәрәкәт итә торган механизмнар.

ПНЕВМОБУШАТКЫЧ *и. тех.* Йөкне кысылган һава ярдәмендә бушата торган җайланмалы машина.

ПНЕВМОКОКК *и. мед.* Пневмония авыруын тудыра торган бактерия.

ПНЕВМОКҮТӘРГЕЧ *и. тех.* Йөкне кысылган һава ярдәмендә күтәрә торган җайланмалы машина.

ПНЕВМОНИ'Я *и. мед.* Үпкә ялкынсынуы. *Консилиум [Галимҗанның] ике үпкәсендә дә аспирация аркасында пневмония башланган дигән карарга килде.* Г. Мөхәммәдова.— [*Баланың*] *үпкәсенә суык тигән. Пневмония.* Х. Сарьян.

ПНЕВМОТОРАКС *и. мед.* Үпкә белән үпкә пәрдәсе (плевра) арасына газ, һава өрдерү. *Якын арада үземне рентгенга алып баралар, шуннан соң, бәлки, пневмоторакс --- ысулын башлау мәсьәләсен куймакчылар.* Г. Ибраһимов.

ПОБЕДИТ *и. махс.* Вольфрамның бик ныклы эретмәсе. *Победитны үткерләгәндә чардан чаткылар чәчрәгән саен, аны хәтерлим.* Х. Гарданов. || *с. мәгъ.* Шундый эретмәдән эшләнгән. *Победит кискеч.*

ПО'ВАР *и. сөйл. к.* пешекче. *1912 елда „Болгар", „Сарай", „Амур" поварлары арасында пәрәмәч пешерүдә узыш башланды.* Г. Тукай.— *Шәехованың этисе — повар, безнең балаларны ул тәмле ашлар пешерергә өйрәтә.* Р. Ишморатова.

ПО'ВАРЛЫК *и. сөйл. к.* пешекчелек. *Син поварлыкка укып, аш остасы булсаң [иде]!* З. Мансур.

ПОВЕ'СТКА *и.* Берәр җиргә килергә кушып язылган кәгазь. *Сугышның икенче көнендә үк миңа да военкоматтан повестка килде.* Н. Дәүли. [*Бай*] *кичке почта илә нотариустан повестка алган.* Ш. Мөхәммәдев.

ПО'ВЕСТЬ *и.* Романнан — сюжетының гадирәк һәм күләменең кечерәк, хикәядән исә зуррак булуы белән аерыла торган әдәби әсәр; озын хикәя. *„Татар хатыны ниләр күрми" повестеның өченче басмасында авыл кулаклары, байларның бөтен җентекле тормышкөнкүреше һәм обстановкалары бирелгән.* Г. Нигъмәти. [*Ш. Камалның*] *„Козгыннар оясында", „Акчарлаклар" кебек атаклы классик повестьлары сезонлы эшчеләр, шахтёрлар, тимер юлчылар тормышын гәүдәләндерделәр.* М. Җәлил.

ПОВИ'ДЛО *и.* Изгән җимешне шикәр белән кайнатып ясалган татлы куе ашамлык, җимеш боткасы. *Алма повидлосы.*

ПОГОН *и.* Хәрби киемдә иңбашка беркетелә яки тегелә торган тар тукымадан гыйбарәт хәрби дәрәҗә билгесе. *Шунда ул Ермиловның погоннарында майор йолдызына игътибар итте һәм Газинур юк чакта Ермиловны комбат итеп күчергәнлекләрен аңлады.* Г. Әпсәләмов. *Стенада подполковник һәм обер-лейтенант погоннары тагылган ике китель эленеп тора.* Ә. Айдар.

ПОГРАНИ'ЧНИК *и. сөйл. к.* чик сакчысы.— *Пограничниклар арасында немецча белүчеләр булырмы икән?* Г. Гали. *Бәхетле киләнең инде мин батыр пограничник булганын да белдем.* А. Шамов.

ПОГРОМ *и.* Берәр милләт яки аерым катлау кешеләрен үтерүдән, кырудан, малларын талаудан гыйбарәт дини-шовинистик чыгыш. *Еврей погромнары.* □ —*Мин әйткән погромның мәгънәсе шул: карагруһ байларга сатылган җыен саяк-сандырык хулиганнар мәдрәсәгә һөҗүм итеп, барыгызны да кыйнап имгәтәчәкләр.* К. Тинчурин. *Карагруһчылар мәктәпкә погром ясыйлар, парталарны ваталар, хәтта укучыларны да кыйныйлар.* Х. Туфан.

ПОГРОМЧЫ *и.* Погром оештыручы, погромда катнашучы кеше. *Тәреле погромчылар төркеме, Воскресенский урамында бер яһүднең кечкенә генә сәгать кибетен талап, кибет артындагы фатирына качкан хуҗасын үтереп, хатынын, балаларын имгәтеп, --- крепостька таба юнәлделәр.* К. Тинчурин. *„Кызыл Байрак" [газетасы] погромчыларның төгәл адресын бик хаклы күрсәтте.* Р. Нафигов.

ПОДА'ГРА *и.* Организмда матдәләр алмашы бозылганлыктан, буыннарга, тукымаларга тоз утырып сызлаудан гыйбарәт авыру. *Чамасыз симергән бер фабрикант атаклы врач Боткиннан: „Сез подагра авыруыннан берәр яхшы чара белмисезме?" — дип сорый.* Каз. утл.

ПОДАУКА *и.* Бер пот әйбер (мәсәлән, орлык) сыешлы агач яки калай савыт. *Сәгыйдә 16 килограмм бодай сыешлы подауканы тутырып, триер аша уздыртты.* М. Әмир. *Батман бирсәң, күп булыр, подаука бирсәң, аз булыр.* Бәет. || *рәв. мәгъ.* Шундый савытка сыярлык, шундый савыт тулы.— *Яңа җиткәнче ашарга бер подаука он, бер капчык бәрәңге биргәннәрие.* Г. Бәширов. || Гомумән иген тутырыр өчен чиләктән зур агач яки калай савыт.

ПОДАУКАЛАП *рәв.* Подаука үлчәве белән; подаукага тутырып, подаука-подаука.— *Миңа бит подаукалап бәрәңге булса да ярый.* Шура. *Нужа төшә дә подаукалап алтынны бирә.* Әкият.

ПОДВАЛ *и.* 1. *сөйл.* Идән асты, нәүрәп; йортның җирдән түбән иң аскы каты. *Камалов, безне урамда калдырып, подвалга төшеп китте.* А. Шамов. *Тревога башлануга, тамашачылар кино астындагы подвалга төштеләр.* Г. Гобәй.

2. Газета битенең зур мәкалә басылган түбәнге өлеше һәм шунда урнаштырылган мәкалә. *Алар кайсы материалны кайда урнаштыру, подвалга нинди мәкалә кертү, бит башына нинди лозунглар бирү турында киңәштеләр.* И. Гази. *Район газетасында „„Галиябану"дан „Гроза"га таба" дигән исем белән дәү бер подвал басылып чыкты.* Г. Бәширов.

ПОДВАЛЧЫ *и. иск.* Читтән килгән сәүдәгәрләрнең малларын үз өенең идән астында саклау белән

шөгыльләнгән кеше, бай.— *Подвалчы Җамалыйлар белән бергәләп казакъларның ике йөз потлап куй маен сеңдергәнсез.* Г. Камал.

ПО'ДДАННЫЙ *и.* 1. Билгеле бер дәүләт гражданы. — *Сез бик яхшы беләсез, мин дә бит Россия подданные идем.* Н. Исәнбәт.

2. *иск. тар.* Эре бай яки князь кул астындагы кеше. *Киев князенең подданныйлары.*

ПО'ДДАННЫЙЛЫК *и.* Берәр дәүләтнең гражданы булу. *Подданныйлык кабул итү. Подданныйлыкны алмаштыру. Россия подданныйлыгына керү.*

ПОДКОМИ'ССИЯ *и.* Берәр махсус мәсьәлә белән шөгыльләнү өчен төп комиссия членнарының кайберләреннән төзелгән кечерәк комиссия һәм шул комиссия членнары. *Подкомиссия сенаторларның санын киметүне мөмкин таба.* Урал.

ПОДКОМИТЕТ *и.* Берәр мәсьәлә белән шөгыльләнү өчен төп комитет составындагы членнарның кайберләреннән төзелгән кечерәк комитет һәм шул комитет членнары. *БМОның Генераль ассамблеясында подкомитет утырышлары.*

ПОДНОС *и.* Савыт-саба яки аш куеп йөртү өчен чите ирнәүле, түгәрәк яки озынча, сай калай яисә пластмасса савыт. *Уң як ишектән, кулына поднос белән чынаяклар күтәреп чыгып, Биби узып бара.* Г. Камал. *Чиновник, денщик тотып торган подностан ике рюмка алып, берсен Искәндәргә сузды.* Г. Гобәй.

ПОДОТЧЁТ *с. махс.* Соңыннан исәпләшү шарты белән тотарга бирелгән (акча турында).

ПОДПИ'СКА *и. сөйл.* Газета-журналлар алдыру өчен төзелгән договор; газета-журналга язылу. *Без яшанабыз: быелгы подписка кампаниясе вакытында укучылар үзләренең сөекле журналларын таратуда җиң сызганып эшләрләр.* Г. Әпсәләмов.

Подписка алу *сөйл.*— кемгә дә булса газета-журналлар җибәрү өчен договор төзү; газета-журналга язу. — *Миннән „Ялкын" журналына подписка алыгызчы.* Г. Галиев.

ПОДПИ'СЧИК *и. сөйл.* Берәр газета-журнал яки китап алдыручы, шул газета-журналларга, китапларга язылучы кеше. *Еллык подписчик күп [түгел], 150 ләп кенә.* Ш. Мөхәммәдев. *Билгеле бер сан (мәсәлән, 300) подписчик табарга сүз бирәсең.* М. Җәлил.

ПОДПОЛКО'ВНИК *и. хәрби.* Армиядә майор һәм полковник дәрәҗәләре арасындагы хәрби дәрәҗә, өлкән офицер чины; шул дәрәҗәдәге хәрби кеше. *Аның бу шашып торган шатлыгына хәтта полк командиры подполковник Кремлёв та игътибар итте.* Г. Әпсәләмов.

ПОДПО'ЛЬЕ *и. сөйл. к.* идән асты. *Подпольедан чыгу.* ▭ — *Абыем минем партия эшчесе иде. Ак чехлар Казанда чагында ул подпольеда эшләде...* А. Шамов. [*Язучы*] *подполье тормышының героик күренешләрен бир[ә].* Г. Кашшаф.

ПОДПО'ЛЬЩИК *и.* Яшерен рәвештә революцион эш алып баручы кеше.— *Мин бу кешедә безнең кул астыннан качып киткән подпольщикны төсмерлим.* Ә. Фәйзи.

ПОДПОРУ'ЧИК *и. хәрби.* Патша армиясендә прапорщиктан бер баскыч югары офицер дәрәҗәсе, чины һәм шул чиндагы кеше. *Бу ел җәйге Тернополь сугышларында подпоручик Зәкәрия Гаян углы Бәхтияровның үтерелгәнлеге рәсми хәбәрдән мәгълүм булды.* Ф. Әмирхан. *12 нче ротаның командиры подпоручик Иванов --- землянкага кереп яткан.* М. Гали.

ПОДПРА'ПОРЩИК *и. хәрби.* Патша армиясендә прапорщиктан бер баскыч түбән гаскәри дәрәҗә, чин һәм шул дәрәҗәдәге кеше.— *Менә тагын берәр батырлык күрсәтсәм, абзагызның подпрапорщик булуын көтегез дә торыгыз!* В. Исхаков.

ПОДРАЗДЕЛЕ'НИЕ *и. хәрби.* Эрерәк хәрби частьтагы гаскәри берәмлек (полкта: батальон, дивизион; батальонда: рота; ротада: взвод һ. б.). *Аннары батальон командирлары сүз алып, үз подразделениеләренең һөҗүмгә хәзерлеге турында информация ясадылар.* И. Гази. *Безнең кайбер подразделениеләребез бер тәүлек эчендә 150 километр юл узалар.* Г. Кутуй.

ПОДРЯД *и. иск.* Билгеле бер хакка берәр эш эшләргә йөкләмә алу һәм шул йөкләмә буенча эшләнелә торган эш. *Подряд алып, юл эшләтергә казнага таш [чыгарабыз].* Г. Рәхим.

ПОДРЯ'ДЧИК *и. к.* подрядчы. *Минем белән калага күчәсеңме?.. Күчсәң, акча бирәм, подрядчик булып, зур йортлар салдырып йөрерсең!* Г. Ибраһимов. [*Сәрхәтев*] *өч-дүрт ел буенча урман подрядчигы булып та йөрде.* Г. Толымбай.

ПОДРЯДЧЫ *и. иск.* Подряд нигезендә эш алып баручы кеше яки оешма.

ПОДСТА'НЦИЯ *и.* 1. Үзәк электр станциясеннән килгән токның көчәнешен, төрен үзгәртә торган электротехник корылмалар җыелмасы; ярдәмче станция. *Трансформатор подстанциясе.* ▭ *Янгын, подстанция дөрес эксплуатацияләнмәү сәбәпле, чыбыклар кушылып китүе аркасында чыккан.* Каз. утл.

2. Ике зур телефон станциясе арасындагы ярдәмче станция.

ПОДСТРО'ЧНИК *и. сөйл.* Берәр текстның сүзгә-сүз, юлга-юл тәрҗемәсе. *Подстрочникны алыйк. Ул да бит үзенә күрә тәрҗемә.* И. Гази.

ПОДТЯ'ЖКА *и.* Чалбарны күтәртеп тоту өчен инбашлары аша үткәрелгән резиналы куш тасма. *Казаки төймәләрен ычкындырып, подтяжкасын күрсәтергә тырышучы изге Фәтхулланың буген ни өчендер тавышы-тыны артык ишетелми.* К. Тинчурин.

ПОДШИ'ПНИК *и.* Машиналарда: әйләнә яки тирбәлә торган детальләрнең шуудагы ышкылуын тәгәрәндәге ышкылуга әйләндерә торган шариклар яки роликлар тезеп ясалган бөжра сыман терәк җайланма. *Роликлы подшипник. Шарлы подшипник.* ▭ *Тракторчылардан берсе, вакытында майламыйча, подшипник яндырды.* Ф. Хөсни. || *с. мәгъ.* Шундый детальләр ясау белән шөгыльләнә торган. *Подшипник заводы.*

ПОДЪЕЗД *и. сөйл.* Өйгә, бинага керә торган ишек. *Подъезд алды.* ▭ *Мәдинә иреккә ярым караңгы подъездның эченәрәк чигенде.* Ш. Хөсәенов.

ПОДЪЕСАУЛ *и. тар.* Казачий гаскәрләрдә патша армиясе пехотасының штабс-капитан чинына тиң гаскәри дәрәҗә, чин һәм шул чиндагы офицер.

ПОДЬЯ'ЧИЙ *и. тар.* Мәскәү Русенда: дәүләт учреждениесендә дьяк ярдәмчесе, приказ канцеляриясендә писарь яки эш башкаручы.

ПО'ЕЗД *и.* Локомотив ярдәмендә хәрәкәткә китерелә торган бер-беренә тоташкан вагоннар. *Тиз йөрешле поезд. Дача поезды. Транзит поезд. Пассажир поезды.* ▭ — *Тимер юлчылар Корниловның контрреволюцион гаскәрләре төялгән поездларын үткәрмиләр.* И. Гази. [*Без*], *бер-берсенә тагылган утыз-кырык вагонны тутырып, бер чакрымга сузылган озын поезд белән бардык.* Н. Фәттах.

ПОЖА'Р *и. сөйл. к.* янгын.— *Ут бараррр!!! Янабыз!!! Пожар! — дигән йөрәккә төшә торган ачы, ямьсез тавышлар минуты белән бөтен авылны чолгап алдылар.* М. Гали. *Столыпинның тапкан бу ысулы гүя Россиядә пожарны бастырган кебек булды. Фәкать бу пожарның басылып торуы вакытча гынадыр.* Ш. Мөхәммәдев.

◇ **Пожар булу** *сөйл.*— бик ашыгыч булу (эш турында).— *Бик ашыгыч эшем бар, пожар булмаса,*

бер ун минуттан керерсең. Ф. Сәйфи-Казанлы. **Пожар чыкканмы (бармы) әллә** *сөйл.*— каты кычкыруга яки ашыгычлыкка ризасызлык белдергәндә, гаҗәпләнгәндә әйтелә.— *Нәрсәгә шулкадәр акырасың, пожар бармы әллә?* Т. Гыйззәт.— *Кая чабасың шулкадәр, пожар чыкканмы әллә?* Р. Ишморат.

ПОЖЫМ *и. диал.* 1. Курку, шик.

2. Берәр бик ашыгыч эшнең хәстәрен күрү уе.

◇ **Пожым керү** — *к.* пожымлау.

ПОЖЫМЛАУ *ф. диал.* Курку, шүрләү. [*Мөкип:*] *Комсомоллар дип мин ялгыш әйткәнмен икән, ул чагында мин сүземне кире алам. Чөнки мин кешедән ишеткәнне генә әйттем.* [*Гариф:*] *Пожымладыңмы?! Кулга алдыру белән шаярырга ярамый шул, Мөкип абзый! Шаярасың икән, үзең килеп капкач, шүрләмә инде.* Ш. Камал.

2. Берәр бик ашыгыч эш белән йөрү.

ПО'ЗА *и.* Гәүдә торышы. *Солдат кына, көзге төн эченә йотыла бара торган борынгы шәһәргә караган хәлдә, һаман шул позада бик озак басып торды.* К. Нәҗми. *Ике позада: берсе караватта утырган, икенчесе аркасына мендәрләр куеп яткан хәлендә Тукайның рәсемнәре алдырылды.* Ш. Әхмәров. || Билгеле бер максат белән гәүдәне эффектлы тоту, эффектлы кыяфәт, кыланыш турында. [*Сөләйман*], *өстәл почмагына сөялеп, кызга карап, Наполеон позасында калды.* К. Тинчурин. *Ике кулын чалбар кесәсенә тыгып, әре генә позада тәмәке тартып, Госман килеп керә.* Һ. Такташ.

ПОЗИТИВ *с.* 1. *махс.* Негативтан төшереп алынган, ак һәм кара өлешләре чынбарлыктагыча булган. *Позитив сурәт.* || *и. мәгъ.* Шундый фоторәсем.

2. Фактларга, тәҗрибәгә нигезләнгән. *Позитив фәннәр.*

3. *кит.* Уңай; *антонимы:* негатив. *Аның күп кенә позитив һәм тәнкыйть фикерләре белән килешергә мөмкин.* Ф. Фасеев.

ПОЗИТИВИЗМ *и.* Идеалистик философиядә: объектив чынбарлыкны һәм әйберләрнең асылын танып белүне инкяр итә, тәҗрибәне субъектив сизemләүләр, күзаллаулар җыелмасы гына дип карый, фәннең күренешләрне, фактларны аңлата алу мөмкинлеген кире кага торган юнәлеш. *Позитивизмга француз философы Огюст Конт нигез салган иде. Ул конкрет фәннең бурычы бары тик тышкы күренешләрнең йөзен тасвирлау дип өйрәтте.* М. Абдрахманов.

ПОЗИТИВИСТ *и.* Позитивизм тарафдары. *Чын философия бары тик фәндәге логик анализ булып кына яши ала диләр позитивистлар.* М. Абдрахманов.

ПОЗИТИВЛЫК *и.* Позитив (2, 3 мәгъ.) булу.

ПОЗИТРОН *и. физ.* Массасы һәм уңай корылмасы электрон корылмасы һәм массасы кадәр булган элементар материаль кисәкчек. *Электрон, мезон, позитрон һәм башка элементар кисәкчекләрнең хәрәкәтендә, бер-берсе белән булган мөнәсәбәтләрендә моңа кадәр фән белмәгән күренешләр ачылган.* М. Абдрахманов.

ПОЗИЦИОН *с.* 1. *хәрби.* Озак вакыт дәвамында сугышчан позицияләрдә алып барыла торган. *Позицион сугышлар булмады диярлек. Без зур дәрт белән алга ургылабыз.* М. Максуд.

2. Шахматта: акрын-акрын яхшы позиция алуга нигезләнгән. *Китапта ябык, позицион уеннар аңлатылмаган.* Ф. Фасеев, Р. Нафигов.

ПОЗИ'ЦИЯ *и.* 1. Сугышта гаскәрләр урнашкан урын. *Артиллерия позициясе. Ут позициясе.* □ [*Суның*] *арьягында, биегрәк бер урында, немецларның позицияләре тора.* М. Гали. *Позициянең шәбен сайладык. Алда — боз, артта — боз, флангтан гына килеп кермәсәләр.* И. Гази. || Сугыш хәрәкәтләре барган урын. *Алгы позицияләр.* □ *Позициягә килеп кергәч, беренче снаряд тетеп ташлады үзен.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Берәр мәсьәләгә мөнәсәбәт, караш. *М. Гафури үзенең бу чордагы шигырьләрендә империалистик сугышка каршы позициягә баса.* М. Җәлил. *Г. Камалның бу чорда язган бөтен әсәрләрендә аның демократик позициядә торганлыгы ачык күренә.* М. Гали.

3. Шахмат, шашка уеннарында уеннның теге яки бу моментында фигураларның торышы. *Сицилия саклануында бик кискен позиция килеп чыкты.* Г. Кашшаф. *Монда, зур материаль югалтуларга карамастан, кораларның позициясе бик көчле, аларның җиңү мөмкинлеге зур.* Р. Нәҗметдинов.

Позиция тоту — 1) сугыш кырында тиешле тәртиптә урнашу. *Дошманга каршы позиция тотар өчен моннан да уңайлы урынны --- таба алмассың.* Ш. Камал; 2) берәр кешегә яки мәсьәләгә карата теге яки бу карашта, мөнәсәбәттә булу.— *Следователь мондый позиция тоткач, мин үзем генә аны боза алмыйм.* Г. Ибраһимов.

ПОЗЫВНОЙ *и. сөйл.* Кайсы радиостанция яки кораб булуын белдерә торган сигнал. *Эфирда радио позывнойлары пипелди башлый.* Ә. Маликов. *Динамик Мәскәү радиосының позывнойларын чыңлатып торды.* Г. Сафиуллин.

ПО'КЕР *и.* Карта уенының комарлы (азартлы) бер төре.

ПОКРАУ *и.* Искечә беренче октябрь көнне була торган христиан бәйрәме. *Җәй, аның артыннан көз үтеп китә. Әллә нинди карлы, яңгырлы, болытлы чаклар килә. Мин иртәгә покрау бәйрәме дигән көндә, ничектер, иртәрәк уяндым.* Г. Ибраһимов. *Покрау үтте — кыш җитте.* Мәкаль.

ПОКРЫ'ШКА *и.* Автомашина, велосипед, мотоцикл һ. б. ш. ның тәгәрмәч камераларына кидерелә торган калын резина тышлык. *Авыл янында басмалар күп. --- Аларның берсе --- автомобиль тәгәрмәчләренең иске покрышкаларыннан гыйбарәт.* Г. Галиев.

ПОЛЕ'МИК *с. кит.* 1. Бәхәс тудыра торган, бәхәсле мәсьәләләр күтәрелгән. *А. Пинкевич „Очерки новейшей татарской литературы" дигән бәхәсле, полемик мәкаләсендә С. Рәмиевне татар поэзиясенең иң алдынгы һәм иң талантлы вәкиле итеп бәяләде.* Г. Халит.

2. Сүз көрәштерүгә, бәхәскә хас, бәхәс өчен характерлы. *Без биредә* [*Һ. Такташның*] *полемик тондырак язылган ике мәкаләсе белән укучыларны таныштырыйк.* Х. Хәйри.

ПОЛЕ'МИКА *и. кит.* Гыйльми, әдәби, политик һ. б. ш. мәсьәләләрне тикшергәндә була торган бәхәс. *Сүз ачы, кискен полемика төсенә кереп китә. Бүлмә тавыш белән каплана.* Г. Ибраһимов. *Сәгыйть Рәмиев үзенең бер шигырендә авыяны идеаллаштырып --- [язган] иде. Биредә Сәгыйть Рәмиевнең ул шигыре белән полемикага керелә.* Н. Исәнбәт.

ПОЛЕМИСТ *и. кит.* Полемиканы оста алып баручы кеше, полемикага оста булган кеше; бәхәсләшергә, сүз көрәштерергә ярата торган кеше.

ПОЛИ- Кушма сүзләрдә „күп" яки „төрле" мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк; мәсәлән: **поливитамин, поликристалл, полиморфизм.**

ПОЛИА'НДРИЯ *и. кит.* Бер хатынның берьюлы берничә ир белән торуы (никахның шундый төре); күп ирлелек.

ПОЛИАРТРИТ *и. мед.* Буыннар шешү, буыннар сызлау. *Ревматизм, инфекцион авырулар яки организмда матдәләр алмашының бозылуы аркасында туган полиартрит ешрак очрый.* Соц. Тат.

ПОЛИВИТАМИН *и.* Күп төрле витаминнар катнашмасы; шундый катнашмадан торган дару.

ПОЛИГА'МИК *с.* Асылы полигамия булган, полигамиягә нигезләнгән. *Полигамик йола.*

ПОЛИГА'МИЯ *и.* 1. Берьюлы берничә хатын яки, киресенчә, берничә ир белән тору; күп ирлелек яки күп хатынлылык.

2. Бер ата хайванны бер сезон эчендә берничә ана хайван белән җенси мөнәсәбәткә кертү.

ПОЛИГИ'НИЯ *и.* Берьюлы берничә хатын белән тору (никахның шундый төре); күп хатынлылык.

ПОЛИГЛОТ *и.* Күп телләр белүче кеше.— *Аңлый алам төрек телен, фарсы телен. Укый алам поляк, болгар телләрендә, Чехча беләм һәм шведча... —Уй-уй! Җитте! Сезнең кебек полиглотка эшең төшсә!* Ш. Мөдәррис.

ПОЛИГОН *и.* Артиллерия тупларыннан атарга өйрәнү яки төрле кораллар сынау мәйданы, урыны. *Бу урын Зеебург полигоны дип атала. Монда яңа алынган солдатларны төз атарга өйрәтәләр.* Ш. Маннур.

ПОЛИГРА'ФИК *с.* Полиграфия ягыннан, полиграфиягә мөнәсәбәтле. *Полиграфик эшләр.* □ *Китапның полиграфик эшкәртелеше әйбәт.* В. Хангилдин.

ПОЛИГРАФИСТ *и.* Полиграфия эшчесе. *Гәрәй Солтан, татар полиграфистлары белән берләшеп, яшерен типография төзеп йөри иде.* Г. Ибраһимов.

ПОЛИГРАФИ'Я *и.* Китап, газета-журнал, һәртөрле плакатлар һ. б. ш. нәрсәләр бастыру производствосы (техниканың бер тармагы). *Иван Харитонов — югары квалификацияле типограф, полиграфия[не] --- сөюче һәвәскәр иде.* И. Рәмиев. *Германиядән полиграфия эшенә өйрәнеп кайткан Мәхмүт Алмаев дигән бер кеше белән [Г. Камал], гектографта басып, „Тәрәккый“ исемле идән асты газетасы чыгара башлыйлар.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Шул производствога бәйләнешле. *Полиграфия комбинаты.*

ПОЛИКЛИ'НИКА *и.* Авыруларга төрле медицина ярдәме күрсәтә, авыруларны карый һәм дәвалый торган учреждение.— *Ух-вах килеп, поликлиникага киттем. Яшь кенә, чибәр генә бер туташ, чишендереп, минем үпкәмне, йөрәкне тыңлады.* Н. Фәттах.

ПОЛИМЕР *с.* Бер-берләреннән молекулаларындагы атомнар саны төрле булу белән генә аерыла торган, бер үк химик төзелешле. *Полимер матдәләр. Полимер кушылмалар.* □ *Синтетик сүсләр, пластик массалар һәм синтетик каучуклар — ясалма полимер продуктлар [алар].* Г. Камай.

ПОЛИМЕРЛАР *и. күпл.* Молекулаларындагы атомнар саны төрлечә булу белән аерыла торган бер үк химик төзелешле матдәләр. *Полимерлар гади молекулаларның бер-бер артлы тоташуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән искиткеч зур химик молекулалардан гыйбарәт булалар.* Сов. әд.— *Металлдан, ярымүткәргечләрдән, полимерлардан мин ижат иткән автомат машиналар болар.* А. Тимергалин.

ПОЛИМЕРЛАШУ *ф. хим.* Бер төрле молекуляр кушылмалардан эрерәк органик молекуляр кушылмалар ясалу. *Эфирларның кайберләре җылытканда --- полимерлаша.* Г. Камай.

ПОЛИМЕРЛЫК *и. хим.* Бер үк төзелешле матдәләрнең молекулаларында икеләтә, өчләтә, дүртләтә һ. б. сандагы атомнар булу күренеше.

ПОЛИМЕТАЛЛ *с.* Составында берничә металл булган, берничә металлдан торган; күп металлы. *Полиметалл руда.*

ПОЛИМОРФИЗМ *и.* 1. *биол.* Бер үк төрдәге тереклек ияләре яки үсемлекләр арасында бер-береннән бик ныык аерыла торган индивидлар булу (мәсәлән, бал кортлары арасында соры кортлар, бал җыючы, сакчы һәм ана кортлар булу). *Җенси полиморфизм.*

2. *хим.* Бер үк матдәнең төрлечә кристаллаша алу үзлеге.

ПОЛИМО'РФИК *с.* Полиморфизм сыйфатларына ия булган, төрле формада очрый торган. *Бал кортларының полиморфик төрләре. Полиморфик үсемлекләр.*

ПОЛИНЕВРИТ *и. мед.* Периферик нервларның бик ныык авыртуыннан һәм сизүчәнлеге кимүеннән гыйбарәт булган ялкынсыну.

ПОЛИНЕ'ЗИЯЛЕ *и.* Тын океан утрауларында (Полинезиядә) күптән яши торган халыкның бер вәкиле.

ПОЛИНОМ *и. мат.* Берничә бербуынның алгебраик суммасыннан гыйбарәт алгебраик аңлатма; күпбуын.

ПОЛИОМИЕЛИТ *и. мед.* Арка миендәге соры матдәнең балалар параличына китерә торган ялкынсыныу (йогышлы авыру); балалар параличы. *Полиомиелит --- яшь балаларда була. Полиомиелит белән авырганда еш кына паралич суга. Тап-таза аяклар, куллар җансыз әйбер кебек салынып кала.* Н. Фәттах.

ПОЛИП *и.* 1. Бер очы белән кузгалмый торган әйбергә береккән, ә икенче очында авызы булган эчәкуышлы хайван. *Җир-су полибы. Мәрҗән полип.*

2. Лайлалы яры өстенә чыга торган куркынычсыз шеш. *Доктор кызның борынында ниндидер полип барлыгын һәм аны кистерергә кирәклеген әйтте.* С. Сабиров.

ПО'ЛИС *и.* Милекне, тормышны страховкалау турында документ.

ПОЛИСЕМА'НТИК *с. лингв.* Күп мәгънәле. *Бу аваз үзгәрешләре --- сүзләрнең күп мәгънәле, полисемантик булуларыннан котылуга чара эзләү ихтыяҗыннан кулеп чыккан.* Г. Алпаров.

ПОЛИСЕМИ'Я *и. лингв.* Бер сүзнең берничә мәгънәгә ия булуы; күп мәгънәлелек.

ПОЛИСМЕН *и.* Англиядә һәм АКШта полицейский. *Полисмен тирләп-пешеп кул болгый, команда бирә, автомобильләрне тизрәк озатып бетерәсе килә.* Г. Гали.— *Теге карчык тагын пароходка килгән иде, порттагы полисмен куып җибәрде.* М. Юныс.

ПОЛИСПАСТ *и. тех.* Йөкләрне бер урыннан икенче урынга җиңелрәк һәм тизрәк күчерү яки күтәрү өчен берничә күчмә һәм кузгалмас блоклар тоташтырылып ясалган механизм.

ПОЛИСТИРОЛ *и. махс.* Электр промышленностенда һәм радиотехникада изолятор сыйфатында файдаланыла торган үтә күренмәле, якты га бирешмәүчән пластик масса. || *с. мәгъ.* Шундый пластик массадан ясалган. *Полистирол торба.*

ПОЛИТ- Кушма сүзләрдә „политик“ мәгънәсен белдерә торган беренче кисәк; мәсәлән: **политбеседа, политграмота, политуку, политмәктәп.**

ПОЛИТБЮРО *и.* Политик бюро. *КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы.*

ПОЛИТБҮЛЕК *и.* Политик бүлек. *Политбүлек начальнигы урынбасары соңгы килүендә, партия-масса эшләренең начар оештырылуын ачып, аларны җанлы, кызыклы формада һәр бригадага, һәр колхозчыга җиткерү чараларын күрсәтте.* М. Җәлил.

ПОЛИТЕЙЗМ *и. кит.* Күп аллага ышануны икърар итә торган дин; күп аллалык.

ПОЛИТЕЙСТ *и. кит.* Политеизм тарафдары.

ПОЛИТЕИ'СТИК *с.* Күп аллага ышана, күп аллага ышануны яклый торган. *Политеистик тәгълимат.*

ПОЛИТЕХНИЗА'ЦИЯ *и. к.* политехникалаштыру. — *Үзегез беләсез, политехнизация чоры, техника дәвере хәзер. Мәктәпләргә хезмәт дәресләре кертелде, машиналар өйрәтелә.* А. Тимергалин.

ПОЛИТЕХНИЗМ *и.* Укучыларны теоретик яктан да, практик яктан да производствоның төп тармаклары белән таныштыруны күздә тоткан уку-укыту системасы.

ПОЛИТЕ'ХНИК *с.* 1. Политехнизмга нигезләнгән. — *Сезнең заводта политехник белем бирү өчен шартлар бик уңай.* Э. Касыймов.

2. *и. мәгъ. сөйл.* Политехника институтында, политехникумда укучы студент яки шул уку йортын тәмамлаган кеше.

ПОЛИТЕ'ХНИКА *с.* Техниканың төрле өлкәләрен өйрәнү һәм кулланыга бәйләнешле. *М. Вахитов Питербург политехника институтына укырга керә.* Р. Нафигов.

ПОЛИТЕ'ХНИКАЛАШТЫРУ *ф.* Политехнизм кертү. *Мәктәпне политехникалаштыру.*

ПОЛИТЕ'ХНИКУМ *и.* Фән-техниканың төрле тармагы буенча урта техник белем бирә торган уку йорты.

ПОЛИ'ТИК I *с.* **1.** Политика (1 мәгъ.) белән бәйләнешле, теге яки бу политиканы тормышка ашыру белән бәйләнгән. *Политик активлык. Политик демонстрация. Политик эшлекле. Политик эшчәнлек. Политик газета.* ▭ *Җәүдәт Мансуров комсомол һәм партия оешмаларында күп еллар эшләде, үз буыны өлешенә туры килгән һәммә политик көрәшләрнең эчендә кайнады.* Г. Бәширов.

2. Политика ягыннан. *Политик аңлылык.* ▭ *Эшчеләрнең һәм крестьяннарның патша Россиясендә бернинди дә политик хокуклары булмады.* М. Җәлил. *„Ящь гомер"[нең] политик иң үткер булган 2 нче пәрдәсенә шундый дөрес бәя — Г. Камалның ул чордагы дөньяга карашын билгеләргә дә мөмкинлек бирә.* М. Гали.

3. Дәүләткүләм хокукый. *Политик режим. Политик строй.*

4. *сөйл.* Бик нечкәләп, оста итеп уйланылган (үзүзен тотыш, эш итү һ. б. ш. турында). *Политик тактлылык.* || Башкалар белән бик оста, нечкә эш итүче (кеше турында). *Дәүләтьяров, әгәр үзенең фикерен тагын да ачыграк итеп әйтергә теләсә: „Урта Азия мөселманнары татар капиталының савым сыерына, ягъни колониясенә әйләнер",— дип тә өстәргә тиеш иде. Ләкин Дәүләтьяров — политик кеше, ул хәтле шыр ялангач итеп сөйләүне яратмый иде.* И. Гази.

Политик тоткын — буржуаз илләрдә революцион хәрәкәттә катнашкан, политик, революцион эш өчен кулга алынып, төрмәгә ябылган, сөргенгә сөрелгән кеше. **Политик экономия** — кешелек җәмгыяте үсешенең төрле баскычларында ижтимагый җитештерү һәм материаль байлыкларны бүлү законнарын өйрәнә торган фән.— *Хәзер барыннан да бигрәк хокук фәнен һәм политик экономияне өйрәнергә кирәк.* Г. Әпсәләмов.

ПОЛИ'ТИК II *и.* **1.** Политик I мәсьәләләр белән шөгыльләнүче кеше, политик эшлекле. *Алдынгы политик. Реакцион политик.* ▭ *Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган [шагыйрь] генә түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит.* Г. Тукай.— *Мөбарәкша — зиһенле егет. --- Шулай күз тимичә барса, милләт өчен зур политик чыгачак аңардан.* К. Нәҗми.

2. *сөйл.* Теге яки бу эшне алдан уйлап, бик оста һәм үткен йөртә белүче, башкалар арасында үзен оста тотучы кеше.— *Салават бит ул хәйләкәр, тәҗрибәле кеше. Сизмисезмени, сестраны ул ничек итеп кармагына эләктерә бара. Ерактан уйлап эш итә ул. Политик.* А. Шамов.

3. *сөйл. иск. к.* политик тоткын.

ПОЛИ'ТИКА *и.* **1.** Дәүләт власте, партия яки ижтимагый төркемнең халыкара мөнәсәбәтләрдә һәм дәүләтнең эчке эшләре өлкәсендә шул власть, партия, төркем интересларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлеге; сәясәт. *Эчке политика. Тышкы политика.* ▭ *Беренче Татар опера театрының төзелүе — --- ул бөек Коммунистлар партиясенең милли политикасы тантанасы.* М. Җәлил. *Патша хөкүмәте милли культураның һәртөрле күренешен буарга омтылды, рус булмаган милләтләрне көчләп „руслаштыру" политикасы үткәрде.* М. Гали. || Халыкара яки дәүләт тормышына бәйле вакыйгалар һәм мәсьәләләр. *Политика белән кызыксыну. Көндәлек политика.* ▭ *Морис исемле бер маклер, политикага керешеп китеп, англичаннарны мактый башлады.* Ш. Мөхәммәдев.— *Нинди кабахәт кеше,— дип уйлады Якуб,— без барыбыз да мөселманнар, имеш, --- тату яшәргә кирәк, имеш. Әллә ул мине политикада бөтенләй сабый дип уйладымы!* И. Гази.

2. *сөйл.* Берәр нәрсәгә ирешү юлында үз-үзен тотыш, билгеле бер төрле эш итү, юл тоту. [*Ул*] *бер эшкә дә катнашмау политикасы алып бара.* Т. Гыйззәт. || Берәр нәрсә эшләргә астыртын ният, хәйлә, мәкер.— *Мин хәзер, фараз иттек, сезнең политикагызны белдем инде, --- безне кулга төшермәкче булгансыз!* Ф. Әмирхан.

3. *сөйл.* Революцион эштә, революцион хәрәкәттә катнашу. [*Галиулла:*] *Таш капчык моннан җиде генә чакрымда, --- утырып караганың юкмы?* [*Якуб:*] *Бер туры килде. Политика өчен, Казанда.* И. Гази.

ПОЛИТИКАН *и. кимс.* **1.** Үз максатына ирешү өчен бертөрле чаралардан да тартынмый торган, мәкерле, хәйләкәр, принципсыз кеше.

2. *сөйл.* Политикадагы төп бурычларны вак-төяккә кайтарып калдыручы, төрле политик темаларга сөйләргә яратудан узмаучы кеше. *Үзләрен тәнкыйтьче дип атап йөргән, әмма „тәнкыйтьләре" теге яки бу язучының үзен һәм аның иҗатын матбугатта сүгүдән, хурлаудан, аңа кара мөһер басудан узмаган шәрә политиканнар: --- „Тукай — безнең шагыйрь түгел, --- ул либераль буржуа шагыйре", --- дип, төрле урыннарда сафсата сатарга керешкәннәр иде.* А. Шамов.— *Хуҗалыктан ераклашсаң, коры политикан булып каласың.* Сов. әд.

ПОЛИТИКАНЛЫК *и.* Политикан булу, үзен политиканнарча тоту. *Политиканлык күрсәтү.*

ПОЛИТИНФОРМА'ЦИЯ *и.* Ил эчендәге яки халыкара көндәлек политик вакыйгалар турында мәгълүмат бирү. [*Университетта*] *политинформацияләр, күңел ачу кичәләре үткәрелә.* Г. Ахунов.— *Иптәш Мәүлитов, иртәгә взводта политинформация үткәрәсез.* Ә. Маликов.

ПОЛИТКАТОРЖАН *и.* Патша Россиясендә: политик, революцион эшчәнлек өчен каторгага сөрелгән, кеше. *Алгы сафта — данлы гвардия, Байкалларны кичкән партизан, Якты гомерен шушы таңга биргән Көмеш чәчле политкаторжан.* Ш. Маннур.

ПОЛИТПРОСВЕТ *и. тар.* Политик мәгариф эшләре белән шөгыльләнә торган оешмаларның, учреждениеләрнең кыскартылган атамасы (XX йөзнең 20—30 нчы елларында кулланылган). *Әхмәт Фәйзи — Арчада политпросвет инспекторы. Ул, авылдан авылга чабып, халыкны, яшьләрне культурага өнди.* Ф. Хөсни.

ПОЛИТРАБО'ТНИК *и.* Армиядә политик тәрбия эшләрен алып баручы кеше. *Немецлар бөтен политработникларны, аларча әйтсәк, комиссарларны рәхимсез рәвештә юк итеп баралар.* Каз. утл. *Мине матбугат булегеннән икенче бүлеккә — политработниклар бүлегенә күчерделәр.* М. Җәлил.

ПОЛИТРУК *и.* 1918—1942 елларда Совет Армиясендә политик эш белән җитәкчелек иткән, үз подразделениесенең политик хәзерлеге һәм сугышка сәләтлелеге өчен командир белән бер үк дәрәҗәдә җавап биргән хәрби җитәкче. *Култык астына газеталар кыстырып, яңадан политрук Исмаев калкып чыкты.* Г. Бәширов. *Дустым, хатың чыннан да, политрук әйтмешли, бик күп кызылармеецларны яңа батырлыкларга рухландыра торган хат булып чыкты.* А. Шамов.

ПОЛИТСОСТАВ *и.* Совет Армиясе һәм флотында хәрби-политик эш алып баручылар составы. *Армиядә мине рациональрәк файдаланып булмыймыни—политсостав яки начсостав итеп?* М. Җәлил.

ПОЛИТТҮГӘРӘК *и.* Марксизм-ленинизмны, КПСС тарихын, философияне, политэкономия һәм агымдагы политиканы өйрәнү түгәрәге. *Уткән ел Солтан укытучылар арасында политтүгәрәк алып барды.* Г. Кутуй.

ПОЛИТУКУ *и.* Политтүгәрәкләргә йөреп, марксизм-ленинизмны, философияне, политэкономияне, агымдагы политиканы һәм КПСС тарихын өйрәнү; политик уку. *Баш инженер политукуларга йөрмәсә дә, бүген ул да --- бирегә сугылган.* Г. Әпсәләмов.

ПОЛИТУ'РА *и.* Агачны ялтырату өчен кулланыла торган спиртлы лак.

ПОЛИТЭКОНО'МИЯ *и.* Политик экономия. [*Андреев*] *шәһәр вузларында политэкономия укытып йөргән укымышлы, интеллигент бер кеше иде.* Ә. Еники. *Уральск чорында ук Тукай Бахның марксистик политэкономия нигезләрен пропагандалауга багышланган „Царь-голод" әсәрен тәрҗемә иткән.* М. Гайнуллин.

ПОЛИТЭМИГРАНТ *и.* Политик эмигрант.

ПОЛИФО'НИК *с. муз.* Полифониягә бәйләнешле; күп тавышлы. *Күп тавышлы, ягъни полифоник планда язылган әсәрләр өчен бу аеруча әһәмиятле.* Р. Башкуров. *Таләпчән остаз Хәбирнең шактый кыю һәм кызыклы эшләнгән полифоник комбинацияләренә, пассажларына булган сокланuын яшер[ми].* Ш. Хөсәенов.

ПОЛИФОНИ'Я *и. муз.* Вокаль яки инструменталь әсәрдә берничә тавыш бергә кушылу; күп тавышлылык. *Алар үзләренең шушы кечкенә оркестрларында кайбер татар көйләрен полифония нигезендә, ягъни төрле тавышта уйнаячаклар икән.* Ә. Еники.

ПОЛИФОНЛЫЛЫК *и. махс.* Күп тавышлылык. *Шагыйрьнең замандашлары арасында аның иҗатындагы бу гражданлык сыйфатларына, шигъри күп тавышлылыгына, полифонлылыгына эчке бөтенлек һәм эзлеклелек хас түгел диючеләр дә булды.* Г. Халит.

ПОЛИХРОМ *с. сәнг.* Күп төсле. *Полихром сурәт.*

ПОЛИХРО'МИЯ *и. сәнг.* Күп төслелек. *Архитектурада полихромия.* □ *Полихромия — ул төрле төсләрне чиратлаштырып буяу, аның үзенең закончалыклары бар.* Каз. утл.

ПОЛИЦАЙ *и. гади с. кимс.* Бөек Ватан сугышында дошман тарафыннан вакытлыча оккупацияләнгән районнарда җирле халыктан хезмәткә алынган полицейский. *Әгәр фашистлар „Красногвардеец"ка кадәр үк барып җитсәләр, шул адәм актыгы Мортыйларны я староста, я полицай итеп куярлар иде.* Г. Әпсәләмов. *Полицайларның күбесе — илен саткан, намусын һәм оятын югалткан кабахәт җаннар.* С. Тажетдинов.

ПОЛИЦАЙЛЫК *и. гади с. кимс.* Полицай булу, полицай хезмәте. *Немецлар тикмәгә генә аларны полицайлыкка һәм шымчылыкка иң кулай элементлар дип санамыйлар шул.* Каз. утл.

ПОЛИЦЕЙМЕ'ЙСТЕР *и. к.* полицмейстер. *Шәһәрнең атаманнары, полицеймейстерлары һәм шуларга охшашлылары да килеп төшеп, --- Недоносковны әллә нинди статья буенча [кулга алмакчы] иделәр.* Г. Тукай.

ПОЛИЦЕ'ЙСКИЙ *и.* Полициядә хезмәт итүче түбән чинлы кеше. *Пристав үзе, өч полицейский белән килә дә, Вахитовны богаулап ала, участокка китерә.* Г. Ибраһимов.

ПОЛИ'ЦИЯ *и.* 1. Патша Россиясендә һәм капиталистик илләрдә буржуаз политик төзелешне һәм иҗтимагый кагыйдәләрнең иминлеген саклый торган махсус орган; шулай ук эксплуататорлар интересын саклый һәм революцион хәрәкәткә каршы көрәшә торган җәза гаскәре. — [*Фрунзены*], *кулга алып, полиция күзәтүе астына җибәргәннәр.* Г. Бәширов. — *Хәзер барам да полициягә хәбәр итәм: --- „Кичә Сабитовның өенә кергән каракның берсе шул", — диярмен.* Г. Камал. || *сөйл.* Шундый орган урнашкан бина. *Европада Төндә йөргән „шикле" кешеләрне Полициягә тотып озаталар.* Һ. Такташ. *Полиция тирәсендә ике-өч меңләп халык җыелган.* Урал.

2. *сөйл.* Полицейскийлардан торган кораллы отряд. *Полиция Искәндәрләрне --- машинага төяп, яңадан төрмәгә алып кайта.* Г. Гобәй. *Мине фашистларның кыр полициясе тотып, Познань төрмәсенә озатты.* М. Хөсәен.

ПОЛИЦМЕ'ЙСТЕР *и.* Патша Россиясенең һәм капиталистик илләрнең зур шәһәрләрендә полиция башлыгы. *Тангатаров әллә кайчан ук шул әдәбият кичәсе ясау турында полицмейстердан рөхсәт ала алмый талашып йөри иде.* Г. Ибраһимов. *Көндезге икеләрдә губернатор кабинетына төсләре китеп агарынган полицмейстер ахылдап керде: „Солдатлар, — диде ул, тыны кысылып, — бистә эшчеләре белән кушылдылар".* К. Нәжми.

ПОЛИЭДР *и. мат.* Бөтен яклары да яссы күппочмаклыклардан торган геометрик җисем; күпкырлык.

ПОЛИЭТИЛЕН *и. хим.* Үтә күренмәле каты полимер (аннан юка капчыклар һәм башка сурәләр ясыйлар). || *с. мәгъ.* Шул продуктан ясалган. *Полиэтилен капчык.* □ *Полиэтилен трубалар су үткәрү линияләрендә күп кулланылалар.* Г. Камай. || *с. мәгъ.* Шундый полимер ясау белән шөгыльләнә торган. *Полиэтилен цехы.* □ *Нелли полиэтилен фабрикында эшли.* А. Тимергалин.

ПОЛК *и.* Гадәттә дивизия яки корпус составына керә торган мөстәкыйль гаскәри берәмлек. *Полк командиры. Артиллерия полкы. Авиация полкы.* □ *Полк комбриг приказында күрсәтелгән вакыт эчендә үзенә билгеләнгән пунктка барып җитте.* А. Шамов. *Тагын бер минуттан бөтен полк аякка баскан, кайсы винтовкасын иңенә салып, кайсы кулына тотып атлый-йөгерә алга таба ашыга иде.* Г. Бәширов.

ПОЛКО'ВНИК *и.* Подполковниктан югары, генералдан бер баскыч түбән офицер дәрәҗәсе, чины; шул дәрәҗәгә ия булган, шул чиндагы офицер. *Потапов башта рядовой солдат, аннан соң хәрби мәктәпләрдә укып, полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән.* Н. Дәүли. *Полк командиры, чибәр генә бер полковник, участоктагы обстановка белән таныштырды.* И. Гази.

ПОЛКОВО'ДЕЦ *и.* Эре гаскәри берләшмәләр, флот һ. б. ш. белән җитәкчелек итүче командующий; гаскәр башлыгы. *Җиңүләрдән җиңүләргә йөрткән гайрәтле полководец — маршал үзе алар белән саубуллашты.* Г. Әпсәләмов.

ПОЛКОВО'ДЕЦЛЫК *и.* Полководец булу. || *с. мәгъ.* Полководец дәрәҗәсенә муафыйк булган, полководецларга хас булган. *Полководецлык сәнгате.*

ПО'ЛКТАШ *с.* Кем белән дә булса бер полкта хезмәт итүче яки хезмәт иткән. *Өй түрендә улаган кышкы җилгә колак салып, [Гафиятулла абзый] полкташ иптәшләрен исенә төшерә.* Г. Әпсәләмов. || *и. мәгъ.* Билгеле бер кеше белән бер полкта хезмәт итүче яки иткән кеше. *Өчесе дә алар — полкташлар, армиядә бергә хезмәт иткәннәр.* М. Хөсәен.

ПОЛЛЮ'ЦИЯ *и. мед.* Йокы вакытында ирләрнең җенси орлыклары ихтыярсыздан бүленеп чыгу.

ПО'ЛО *и.* Командаларга бүленеп, атка атланган килеш туп уйнау.

ПОЛОВОЙ *и. иск.* Трактирда, кечерәк кунакханәләрдә хезмәтче. *Анда әледән-әле кыска алъяпкычлы җитез половойлар йөгереп уза. Алар, ашамлык өелгән подносларны жонглёр осталыгы белән тотып, җәлт иткәнче тиешле бүлмәгә илтеп тапшыралар.* А. Расих. *Ул чагында половойга, иренмәсәң, коридорга чыгып кычкырасың.* Ж. Вәлиди.

ПОЛОЖЕ'НИЕ *и.* **1.** Билгеле бер мәсьәлә буенча кагыйдәләр, законнар җыелмасы. *Сайлаулар турында положение.* □ *Положение буенча аларның үз оешмалары булырга тиеш.* Соц. Тат.

2. Берәр чыгышта, мәкаләдә һ. б. ш. төп фикер, тезис. *Диалектик материализм положениеләре.*

ПОЛОНЕЗ *и.* **1.** Өч тактта торган тантаналы бал биюе һәм шул биюнең музыкасы. *Генерал Гремин сараенда бара торган бал кичәсендә аристократлар арасында таралган полонез яңгырый.* Ж. Фәйзи.

2. Шул бию тактына язылган музыкаль әсәр. *Огинскийның полонезын --- егет онытылып уйнарга кереште. --- Кешенең катлаулы кичерешләрен сөйли торган бу полонезны Назыйм үзе дә сөя иде.* М. Кәримов. — *Сугыш елларында бөтен экипажыбыз белән гашыйк идек без ул полонезга.* Б. Камалов.

ПОЛО'НИЙ *и. хим.* Үзенең сыйфатлары, үзлекләре белән теллурга һәм висмутка охшаш радиоактив химик элемент.

ПОЛОСА *и.* **1.** Урман, кыр, җир һ. б. ш.ның билгеле бер озынлыкка сузылган кисәге; зона. *Кара туфраклы полоса. Ышыклау урман полосасы.* □ *Дәбәт үссен булган полосалар, Мәсьәләнең шунда мөһиме!* Ш. Мөдәррис.

2. *махс.* Газета-журнал яки китапта басма текстның бер бите. *Басу машинасына иң элек беренче белән дүртенче битләрнең полосалары бирелә.* Г. Минский.

ПОЛОТНО *и.* **1.** Һәр буй җебе һәр аркау җеп белән үрелгән бизәксез киндер яки киже-мамык тукыма; шулай үрелеп тукылган ясалма ефәк тукыма. *Штапель полотно.* □ *Фәкать шул җирдә генә инде Фәтхулла хәзрәт бу татарның чын кеше түгел, бәлки рәсем генә икәнен һәм бу „Көфер почмагы“ булып күренә торган нәрсәнең дә бик зур полотнога ясалган картина икәнен белде.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. [*Хәсәнша*] *җәй көне соры полотно казаки белән шул ук тигез түбәле каракүл бүрекне кия.* Ш. Камал.

2. Гадәттә киндергә ясалган картина. *Шишкин полотносы.* □ *Бу ярым подвал сыман бүлмә художник Репин кулы белән полотнода мәңгеләштерелгән.* Ә. Еники. *Бөек рус художнигының дәһи полотнолары аны шулкадәр дулкынландырган.* Г. Кашшаф. || Тормышны, теге яки бу вакыйганы төрле яклап киң сурәтли торган күләмле әдәби әсәр. *Безнең тормышның героикасын киң полотнода сурәтләү.*

3. Тимер юл, шоссе һ. б. ш. юлларның таш, чуер-таш, ком һ. б. ш. нәрсәләр өелгән нигезе, дамбасы. *Җир полотносы яхшырак утырсын, басылсын өчен --- эш транспортын балчык-ком өеме өстеннән җибәргәннәр.* М. Хәсәнов. — *Тимер юл полотносын сакларга куелган* [*кешеләрегез*] *качып беттe.* Ш. Маннур.

ПОЛПРЕД *и.* Тулы хокуклы вәкил (СССРның чит илләрдәге дипломатик вәкиленең 1941 елга кадәрге атамасы).

ПОЛПРЕДЛЫК *и.* Тулы хокуклы вәкиллек (СССРның чит ил хөкүмәте янындагы дипломатик вәкиллегенең 1941 елга кадәрге атамасы).

ПОЛТЫРАК *с. диал.* Тузгак (чәч турында).

ПОЛТЫРАНУ *ф. диал.* Тузгу, таралу (чәч турында). *Аның полтыранган аксыл чәче башын бик зур итеп күрсәтә.* Н. Фәттах.

ПОЛТЫРАУ *ф. диал.* Ашыгу; тузгу. *Полтырап йөрү.*

ПОЛУБОТИ'НКА *и.* Кунычсыз, сай ботинка. *Әнвәрнең үзенә брезент булса да полуботинка сатып алырга ниятләделәр.* Э. Касыймов. [*Әгать*] *яхшы трикодан, полуботинкалардан.* Ә. Фәйзи.

ПОЛУВА'Л *и.* Үгез яки сыер тиресеннән эшләнеп, олтан итеп файдаланыла торган тупас күн.

ПО'ЛЬДЕР *и. махс.* Төньяк диңгез яр буенда дамба белән уратып алынган, киптерелгән һәм авыл хуҗалыгы культуралары игелә торган иңкү җир.

ПО'ЛЬКА I *и.* **1.** Ике тактлы җитез бию һәм шул бию көе. *Полька, мазурка, тустепларга биегәннән соң, „Көзге хыяллар“ вальсы башланганда, ут сүнде.* И. Туктар.

2. Шул бию ритмындагы музыкаль әсәр. *Рахманинов полькасы.*

ПО'ЛЬКА II *и.* Чигәләрдәге һәм баш артындагы чәчне бераз гына кыркудан гыйбарәт чәч алу ысулы.

ПО'ЛЮС *и. сөйл.* **1.** Җир шары уйланма күчәренең җир өстендәге ноктасы; котып. *Көньяк полюс.* || Шул уйланма күчәр тирәсендәге урын. *Көньяк полюска экспедиция оештыру.* □ *Төньяк полюсны өйрәнүче батыр галим Фритьоф Нансен --- империалистик даирәләрнең Советлар Союзына каршы корткычлык эшен гаеплә чыкты.* К. Фасеев.

2. *физ.* Электр чылбырының капма-каршы ике очының берсе. *Уңай полюс. Тискәре полюс.* □ *Мускул очларына электр импульсларын ешрак бирep, полюсларны үзгәртеп торырга кирәк.* А. Тимергалин. || Магнит яки электромагнитның капма-каршы очларының берсе.

Полюс башмагы *тех.* — приборда даими магнит полюслары белән деталь арасында була торган аралыкны киметү өчен полюска (2 мәгъ.) кидертелә торган корыч өстәмә. **Полюс тапкыч** *тех.* — даими ток чылбырындагы ток полюсларының уңаен һәм тискәресен таба торган прибор.

ПОЛЯК *и.* Польшаның төп халкын тәшкил иткән көнбатыш славян халкының атамасы; шул халыкның бер вәкиле. *Алар бергәләп поляк партизаннары өчен күп кенә корал частьлары чыгаралар.* Ш. Маннур. *Поляк милләте үз тарихының иң* [*бөек*] *сәхифәләреннән берсен уздыра торган ушбу көннәрендә зур бер матәм тотарга мәҗбүр булды: Польшаның иң шөһрәтле вә гаять зур мәхәббәт казанган мөхәррире Генрих Сенкевич вафат итте.* Ф. Әмирхан.

ПОЛЯ'КЧА *рәв.* Поляк телендә. *Ул полякча оста сөйләшә иде.* А. Расих. — *Безнең җирләремездә полякча сөйләргә бирмилəр.* Урал. || *сөйл.* Поляк телендә сөйләшү турында. *Кутуй аз-маз полякча белә.* Г. Галиев.

ПОЛЯР *с.* **1.** Полюс (1 мәгъ.) тирәсенә урнашкан, полюс (1 мәгъ.) тирәсендәге. *Поляр утраулар. Поляр шәһәр.* || Полюс тирәсендә эшләү белән бәйле. *Поляр станция. Поляр экспедиция.* || Полюс тирәсендә, поляр түгәрәк артында яши яки үсә торган. *Поляр акула. Поляр ябалак.*

2. *физ.* Уңай һәм кире корылмалар булу белән үзенчәлекле. *Поляр кушылмалар. Атомнарның поляр төркемнәре. Поляр бәйләнеш.*

Поляр балкыш — атмосфераның югары катлауларында яктылык нурлары чәчелү күренеше (ул поляр түгәрәк артында яхшырак күренә). **Поляр казы** *зоол.* — үрдәксыманнар семьялыгыннан поляр зонада яши торган кош; *русчасы:* морянка. **Поляр көн** — поляр түгәрәк артында кояш айлар буена батмый торган чор. **Поляр төн** — поляр түгәрәк артында айлар буена кояш чыкмый торган вакыт. *Үзенең каты салкыннары, кар бураннары, поляр төне белән* [*Таймырда*] *кыш бик*

озак дәвам итә. Каз. утл. **Поляр түгәрәк** — салкын пояснының чиге булып саналган һәм экватордан Көньякта һәм Төньякта 66°32′та яткан параллель. *Нәрсә ул Таймыр? — Поляр түгәрәктән дә төньякка табарак шактый ераккa урнашкан ярым утрау ул.* Каз. утл. *Хәзер инде [нефтьчеләр] поляр түгәрәккә барып җиттеләр!* Каз. утл.

ПОЛЯРИЗА'ТОР *и.* Яктылыкны полярлаштыру приборы.

ПОЛЯРИМЕТР *и.* Яктылыкның полярлашу дәрәҗәсен, полярлашу яссылыгының борылыш почмагын үлчәү приборы.

ПОЛЯРИСКОП *и.* Яктылыкның өлешчә полярлашуын билгели торган прибор.

ПОЛЯРЛАШТЫРУ *ф. физ.* Полярлашу барлыкка китерү. *Электромагнитны полярлаштыру.*

ПОЛЯРЛАШУ *ф. физ.* **1.** Табигый яктылык чыганагыннан килгән яктылык дулкыннарының электр һәм магнит кыры көчәнешлелеге төрле юнәлештә төрлечә булу. *Яктылык полярлашу.*

2. Электродларда электр тогының көчен киметә торган төрле матдәләр утыру. *Гальваник элемент полярлашу.*

ПОЛЯРЛЫК *и. физ.* Электр чылбырында полюсларның үзара мөнәсәбәте, бәйләнеше, бүленеше.

ПОМА'ДА *и.* Иренгә сөртү өчен төрле хуш исле матдәләр катнашмасыннан торган косметик май. [*Камилә*], *күлмәк кесәсенә кулын тыгып, ирен помадасы ала. Иреннәрен буйый.* Г. Камал.

ПОМА'ДКА *и.* Хуш исле йомшак конфет төре. *Җимеш помадкасы.* □ *Без, аның учындагы сары һәм ал помадкаларны алып, урамга чыгып чабабыз...* Ж. Фәйзи.

ПОМЕ'ЩИК *и. сөйл. к.* алпавыт. *Элекке помещиклар строен кире кайтару өчен сугышучы ак бандитлар крестьяннарның җир турындагы сүзен ишетү белән дә котырып катәләр.* М. Җәлил. *Йортлар киң кырларга сибелеп утырганнар. Ара-тирә элекке помещик имениеләре күренәләр.* Г. Гали.

ПОМИДОР *и.* **1.** Эт җиләге (паслёнчалар) семьялыгыннан булган үсемлек. *Хатын-кызларның кайберләре кәбестә, помидор үрентеләре утырта.* Ш. Камал.

2. Шул үсемлекнең кызыл төстәге җимеше. *Помидорлар пешеп кызарды һәм җиргә иелде.* М. Җәлил.

ПОМОР *и.* Ак диңгез һәм Төньяк Боз океаны яр буйларында күптәннән бирле яшәүче рус кешесе.

ПО'МПА *и. махс.* Газ яки сыеклык кудыра торган насос.

ПОМПАДУР *и. кит.* Ни теләсә шуны эшләргә ярата торган дуамал администратор. *Россия империясенең помпадурлары һәм помпадуршалары [Февраль революциясеннән соң да] дәүләт белән идарә итәләр.* Р. Нафигов.

ПОМПАДУРЛЫК *и.* Помпадур булу.

ПО'НИ *и.* Вак токымлы ат. *Пони бик шаян, бик азгын булганга, аның белән уйнап көн үткәрү балалар өчен бик күңелле була.* Ак юл. *Кечкенә ат — пони — зоопаркта балалар күңелен ачуга хезмәт итә.* И. Нуруллин.

ПОНОМАРЬ *и.* Православие чиркәвендә иң түбән дәрәҗәдәге рухани, поп ярдәмчесе. *Ишетмәгән пономарьга ике рәт чаң какмыйлар.* Мәкаль. *Чаңы да ишетелми, әллә чаң кагучы пономарь исерек?* Г. Әпсәләмов.

ПОНТОН *и.* **1.** Вакытлыча салынган күперне яки башка корылмаларны суда күтәреп тора торган яссы төпле көймә. *— Елгада понтоннар йөри башлады.* Х. Госман. *Бу понтоннардан 12—16 тонна йөк күтәрелек өч пароm җыярга мөмкин.* Г. Сафиуллин. || Шундый көймәләр өстенә вакытлыча салынган күпер. *— Су уртасындагы понтон өстенә граната килеп төшә. Әгәр ул шартласа, без Днепрны тиз генә кичә алмыйбыз.* К. Нәҗми.

2. Баткан корабларны күтәрү өчен кулланыла торган эче куыш зур савыт.

Понтон күпер — көймәләр өстенә вакытлыча салынган күпер. *Висланың уң як ярында --- карлы-бозлы яңгырлардан күшегеп ятучы частьлар --- байтак җыелган, берничә понтон күпер генә аларны үткәреп бетерә алмый иде.* Ф. Хөсни. *Иртышның икенче ягындагы Яңа Семейгә понтон күпер аша җәяүләп чыктым.* Н. Фәттах.

ПОНТОНЧЫ *и.* Инженерлык гаскәрләрендә понтоннар төзү, понтон күперләр салу белән шөгыльләнүче хәрби хезмәткәр. *Ул иртәнгә кадәр безнең корпус кичкән полосада --- сапёрлар һәм понтончылар эше белән җитәкчелек итте.* Г. Сафиуллин.

ПО'НЧО *и.* Үзәк һәм Көньяк Америка индеецлары киеп йөри торган һәм уртасыннан баш сыярлык тишек уелган дүрт читле калын шәлдән гыйбарәт өсьяпма.

ПОП *и.* Православие динендә: рухани. *Поп, үзенең кулындагы „Евангелие“не ачып, бер кулы белән ерактан ук [фатиха биреп], кычкырып нәрсәдер укып, Егорычка таба килә башлады.* М. Гали. *Арба артыннан тәре күтәргән хисапсыз поплар, чиновниклар, монахлар, монашкалар койрык булып әкрен генә кузгалдылар.* М. Гафури.

ПОПЕЧИ'ТЕЛЬ *и.* Патша Россиясендә: берәр ведомство (күбесенчә, мәгариф ведомствосы) учреждениеләре белән җитәкчелек итүче яки берәр учреждениенең почётлы җитәкчесе итеп билгеләнгән кеше. *Попечительләр советы.* □ *Казан университетындагы уку-укыту эшләрен тикшереп, күзәтеп тору өчен, Казан укыту округының попечителе итеп --- Румовский билгеләнә.* Ж. Тәрҗеманов. *— Мәгариф министры, әгәр студентлар арасында чуалыш була калса, йомшаклык күрсәтмәгез дип, попечительне кисәтеп куйган.* Р. Ишморат.

ПОПЕЧИ'ТЕЛЬЛЕК *и.* Попечитель вазифасы, попечитель урыны. || Попечитель булу.

ПОПЛИН *и.* Вак аркылы сырлы ефәк, ярым ефәк яки киҗе-мамык тукыма. *Кызлар --- поплиннан тегелгән озын күлмәк [киялар].* Г. Таһиров. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Поплин күлмәк.*

ПОПЛЫК *и.* Поп булу. *Думага член булып киткән поп Архипов поплык[тан] чыгарылган.* Урал.

ПОПУГАЙ *и. сөйл.* **1.** *к.* тутый кош. *— Ул, сиңа әйтим, [бүлмәдә] клиндер койрыклы этләр дисеңме, попугайлар дисеңме...* Һ. Такташ. *Попугай инде „исәнме“, „сау бул“ дигән сүзләрне --- әйтә ала.* Р. Мостафин.

2. *күч.* Үзенең шәхси фикере булмыйча, башка кеше сүзен, фикерен кабатлаучы кеше. *Бу дөньяда --- Тимербай исемле агач попугайлар [күп].* Г. Тукай.

ПОПУГАЙЛАНУ *ф. сөйл.* Үз фикере булмыйча, башка кеше фикерен, сүзен кабатлап тору.

ПОПУГАЙЛЫК *и. сөйл.* Үз фикере булмыйча, башка кеше фикерен, сүзен кабатлау сыйфаты.

ПОПУЛЯР *с.* **1.** Һәркемгә дә аңлаешлы; эчтәлеге, язылышы, сөйләнеше белән гади. *Популяр лекция.* □ [*Элекке татар врачларының*] *берсе дә, шундый популяр әсәр язып, үзенең белемен халык белән уртаклашмаган.* И. Рәмиев. || *рәв. мәгъ.* Һәркемгә аңлаешлы, гади итеп. [*Тукайның*] *икенче төрдәге иярүләренә татарның озын яки кыска көйләреннән берәрсе үлчәвенә салынып, гади телдә, популяр язылган лирик шигырьләре керә.* Г. Нигъмәти.

2. Киң җәмәгатьчелек арасында билгеле, танылган, халыкның мәхәббәтен казанган. *Популяр артист.* □

Җыр — музыка сәнгатенең иң таралган, иң популяр жанры. Ж. Фәйзи. *Революциядән соң күтәрелгән татар совет язучылары арасында Такташ — иң популяры, башка шагыйрьләргә караганда киңрәк, күбрәк катлау укучылар арасында танылганы.* Г. Нигъмәти. || Бик киң таралган, һәркемгә дә билгеле. *Популяр журнал. Популяр уен коралы.*

ПОПУЛЯРЛАШТЫРУ *ф.* 1. Берәр фикерне, әсәрне һ. б. ш. ны киң халык массасына аңлаешлы, гади телдә, артык катлауландырмыйча язып яки сөйләп бирү. *Фәнни хезмәтне артык популярлаштырып язу.*

2. Берәр фикерне, эшне, хезмәтне һ. б. ш. ны халык арасында киң тарату, киң җәмәгатьчелеккә билгеле итү; пропагандалау. *Г. Камал Тукай үлгәннән соң аның шигырьләрен популярлаштыра.* М. Гали. | *и. мәгъ. Конкурсның әһәмиятен һәм бурычларын киңрәк һәм өзлексез популярлаштыру йомшак.* М. Җәлил.

ПОПУЛЯРЛАШТЫРУЧЫ *и.* Теге яки бу хезмәтне, фикерне, әсәрне һ. б. ш. ны киң җәмәгатьчелеккә җиткерүче, халык арасында билгеле итүче кеше. *Халык җырларын популярлаштыручы.*

ПОПУЛЯРЛАШУ *ф.* Популяр булып китү, киң таралу. *Марксизм идеяләре популярлашу.*

ПОПУЛЯРЛЫК *и.* Киң җәмәгатьчелеккә танылу, җәмәгатьчелек тарафыннан сөелү. *„Һиҗрәт“ пьесасы бик хуплап каршы алынды һәм ул зур популярлык казанды.* Х. Сәлимҗанов. *„Тапшырылмаган хатлар“ повесте Кутуйга зур популярлык китерде. Ул, рус теленә һәм Советлар Союзында яшәүче башка халыкларның телләренә тәрҗемә ителеп, халыкның яратып укыла торган китабына әверелде.* Сов. әд.

ПОПУРРИ *и.* Халык арасында киң таралган, яратып уйнала, җырлана торган җыр-биюләрнең, опера ариясеренең аерым өзекләреннән төзелгән музыкаль әсәр. *„Шәрык балеты“ --- безнең халкыбызга бик якын таныш—попурри—тезмә формасында язылган.* Ж. Фәйзи.

ПОРАК: порак оны *диал.* — тегермән стеналарына мамыктай булып куна торган вак он тузаны; онта. *Менә тышкы стеналарына порак оны кунган кечкенә генә тегермән өе.* Ш. Маннур.

ПОРНОГРА'ФИК *с.* Җенси мөнәсәбәтләр белән бәйләнгән күренешләрне, эшләрне бик оятсыз, әдәпсез рәвештә сурәтли торган. *Порнографик әдәбият. Порнографик фоторәсемнәр.* □ *1910—12 елларда „урам әдәбияты“ дигән исем алган, эче-тышы арзанлы, порнографик гыйбарәләр кулланудан да тартынмаган әйберләр басыла.* И. Рәмиев.

ПОРНОГРА'ФИЯ *и.* Җенси мөнәсәбәтләр белән бәйле нәрсәләрне, эшләрне сурәтләүдә әдәпсезлек, кирәгеннән артык оятсызлык. — *Без һаман әле милли капитал кыргаякларының порнографияләре белән массаны сыйлыйбыз.* К. Тинчурин.

ПОРОЛОН *и.* Күзәнәкләрдән торган, җиңел, йомшак, эластик полимер материал. || *с. мәгъ.* Шундый материалдан ясалган. *Поролон матрац.*

ПОРОШОК *и.* 1. Каты матдәнең төеп, тузан хәленә китерелгән төре. *Теш порошогы. Кара порошогы. Йомырка порошогы.* □ [*Кызылармеец*] *туалет әйберләре тутырылган несессердан бритва белән сабын порошогын ал*[*ды*]. Ш. Усманов.

2. Бик вак итеп төелгән дару. *Порошок кабул итү. Йоклата торган порошок.* □ [*Ул*], *аптырагач, порошоклар йотып та карады — булмады, күзләреннән йокы бөтенләй качты.* М. Хөсәен. *Шикле* [*кеше*] *ятканурынына, эзләренә ниндидер порошок сибеп чыгып китә.* А. Әхмәт. || *с. мәгъ.* Төелгән. *Порошок дару.*

ПОРОШОКЛАТА *рәв.* Порошок рәвешендә. —*Алып кайтыйм мин сиңа шәмәхә буяу. Порошоклата сатыла ул.* Ф. Хөсни.

ПОРСАЛАНУ *ф. диал.* Борчылу, тынычсызлану, үз-үзен кая куярга белмәү; борсалану.

ПОРТ *и.* Суднолар, кораблар туктау, йөк төяү яки бушату, судноларны ремонтлау өчен махсус җиһазланган урын. *Диңгез порты. Елга порты. Сәүдә порты.* □ *Причалларында таш пулаттай икешәр-өчәр катлы пароходларны, трамвай хәтле зур-зур ящикларны җиңел генә күтәреп баржаларга төйи торган корыч кранналар --- белән порт көндез дә, төнлә дә бертуктаусыз гөр килеп тора.* С. Сабиров. || Суднолар, кораблар тукталу, йөк төяү яки бушату, ремонтлау өчен махсус җиһазланган урыны булган диңгез, зур күл яки зур елга буе шәһәре. *Зур диңгезнең кораблары Керә Казан портына.* Х. Вахит.

ПОРТАЛ *и.* 1. Зур бинаның яки тоннельнең бизәкләп, матурлап ясалган ишеге, капкасы. *Тоннельнең керү порталы бетонланган инде.* А. Сәләхетдинов. *Җыйнак ишек алдына керәсең. Ул төп порталга алып килә.* Каз. утл.

2. *тех.* Машинаның „П“ хәрефе рәвешендә ясалган рамы (бер өлеше).

ПОРТАЛЬ *с. тех.* Аскы яки төп өлеше, рамы „П“ хәрефе рәвешендә ясалган. *Порталь станок.* □ *Әллә ничәшәр тонналык йөкләрне уйнагандай гына итеп һавага чөеп, порталь кранналар әйләнеп тора.* Г. Әпсәләмов.

ПОРТАТИВ *с.* Кечкенә күләмле, йөртергә уңай. *Портатив фотоаппарат. Портатив язу машинасы.* □ *Гертц төрмә больницасына кечкенә генә чемоданда портатив магнитофон алып килгән.* Соц. Тат.

ПОРТАТИВЛЫК *и.* Кечкенә күләмле һәм йөртергә уңайлы булу сыйфаты.

ПОРТВЕЙН *и.* Составында спирт күп булган көчле кызыл аракы сорты. — [*Хәлим*] *шүрлектән портвейн алып эчкән дә, инде хәзер, күрәсең, аягына да басып тора алмый...* Г. Гобәй. *Кыстый торгач, ул да бер ярты стакан чамасы портвейнны бүлгәләп кенә эчеп куйды...* Ә. Еники.

ПО'РТИК *и. махс.* Күбесенчә бинага тоташтырылып, түбәсе ябулы итеп эшләнгән коллонналы галерея. *Һәрберсе сигез квадрат колонналы портикка нигезләнгән монастырьның өч яруслы фасады геометрия һәм тригонометриягә нигезләнеп эшләнгән, әлбәттә.* М. Мәхмүтов.

ПОРТМОНЕ(Т) *и. иск.* Акча салып йөртү өчен кечерәк күн янчык. [*Хәсән*] *кесәсеннән портмонесын чыгарды да ямщикка унбиш тиен акча бирде.* Ф. Әмирхан. *Биктәһир карт портмонетны ачып, аның урта бүлекчәсеннән бер сумлык кәгазь акча тартып чыгарды.* И. Гази.

ПО'РТО-ФРА'НКО *и. махс.* 1. Портның пошлинасыз товар кертү яки читкә чыгару хокукы.

2. Шундый хокукка ия булган порт. *Сәүдәгәрләрне һәм сәүдә капиталын үзенә тарту өчен Сингапур порто-франко, ягъни пошлинасыз сәүдә порты дип игълан ителә.* Р. Мостафин.

ПОРТРЕТ *и.* 1. Рәсем сәнгатендә, сынлы сәнгатьтә, фотографиядә: билгеле бер кеше яки кешеләр төркеме сурәте. *Стеналарда алтын путаллы һәм буяулы рамнарда Толстойлар нәселендәге кешеләрнең, Лев Николаевичның үзенең һәм семья членнарының портретлары... Бу портретларның күбесе бөек художниклар кулы белән язылган.* Ә. Еники. *Конверт эченнән бер егет портреты килеп чыкты.* Ф. Әмирхан.

2. Әдәби әсәрдә персонажның тышкы кыяфәтен сурәтләү. *Портрет язганда* [*Г. Бәширов*] *тышкы кыяфәт белән рухи дөнья сызыкларын тәңгәл китереп, бер бөтен итеп сурәтли.* Б. Камалов.

ПОРТРЕТЧЫ *и.* Сынлы сәнгатьтә: портрет ясаучы, портрет язучы. *Рафаэль — шәп портретчы.* Г. Гали.

— Мин үзем портретчы түгел. Шулай да ясадым инде: мондый кешеләрне ничек калдырып китәсең ди! Э. Касыймов.

ПОРТСИГАР *и.* Папирос яки сигара салып йөртелә торган яссы тартма. *Пристав көмеш портсигарыннан папиросын алып кабызды.* М. Гафури.

ПОРТУГАЛ *и.* Португалиядә яшәүче төп халык һәм шул халыкның бер кешесе. || *с. мәгъ.* Шул халыкка бәйләнешле. *Португал теле. Португал әдәбияты.*

ПОРТУГА'ЛИЯЛЕ *и.* Португалиядә яшәүче халык кешесе. *Португалияле сәяхәтче Васко да Гама диңгез аша Һиндстанга юл эзли.* А. Расих.

ПОРТУГА'ЛЧА *рәв.* Португал телендә. *Португалча сөйләшү.*

ПОРТУПЕ'Я *и.* Корал тагып йөртү өчен иңбашы аркылы үткәрелгән каеш. *[Наилнең] портупеясы, погон асларыннан үткәрелеп, ипләп ныгытылган.* Г. Әпсәләмов. *Хәмит этисенең шинеленә, биленә буылган киң каешына, портупеясына һәм наганына күз төшерде.* С. Шакир.

ПОРТФЕ'ЛЬ *и.* **1.** Китаплар, дәфтәрләр, төрле эш кәгазьләре салып йөртү өчен каптырмалы, тоткалы дүрткырлы сумка. *Күн портфель. Кара портфель.* □ *Төрле язулар, карта һәм башка документларны алып подполковникның өстәл өстендә яткан портфеленә тутырдым.* Ә. Айдар.

2. Министр урыны, министр хезмәте. *Портфель бүлешү.* □ *Ораторлар [анда] ялган пафос сата, Министрлар портфель саталар.* Г. Афзал. || *сөйл. мыск.* Гомумән зур эш урыны. *Ә инде берәрсе, начальник яки түрә булып алгач, менеп утырган креслосын, портфелен югалта башласа, беттe!* М. Хәсәнов.

3. Редакция, нәшрият басарга кабул иткән кулъязмалар, сәхнәдә куярга алынган кулъязмалар. *Хәзерге безнең репертуар портфелендә гел драматик сюжетка язылган либреттолар гына.* М. Җәлил.

ПОРТФЕЛЬСЕЗ: портфельсез министр — кайбер капиталистик илләрдә дәүләт идарәсенең аерым бер тармагы белән җитәкчелек итмичә, бары тик махсус йомышлар үтәүче министр.

ПОРТЧЫ *и.* Порт эшчесе, порт хезмәткәре.

ПОРТЬЕ *и.* Кунак йортының ишек төбендә, вестибюлендә тәртип саклаучы, почта таратучы хезмәткәр.

ПОРТЬЕР *и.* Ишеккә яки тәрәзәгә эленә торган калын пәрдә. *Эскәтерләрне, портьерларны матурлау өчен төрле төслəр белән чигәргә мөмкин.* Йорт эшләре.

ПОРУ'КА: порукага алу — суд тикшерүе астындагы кешене ябылу урыныннан кемнең дә булса яки берәр оешманың җаваплылыгына алу. *— Әтине һәм башкаларны төрмәдән порукага алып җибәреп карыйм әле.* Һ. Такташ. *— Әше тикшерелеп ачыкланганчы, без [Биктимерне] Григорий Мироныч белән порукага алып торырбыз.* Т. Гыйззәт.

ПОРУ'ЧИК *и.* Патша армиясендә (хәзер Польшада) подпоручиктан бер баскыч югары булган офицер чины һәм шул чиндагы кеше. *— Бу шинель эчендә --- провокатор Сәгыйтов. Чины — поручик.* Г. Гобәй. *Пароходка бер төркем солдат белән яшь кенә бер поручик килеп керде.* С. Сабиров.

ПОРФИР *и.* Кайбер эре кристаллары үзләренең зурлыклары яки төсмере белән төп массадан аерылып тора торган вулканик тау токымы. *Эффузив токымнарга --- кварцлы порфир керә.* А. Фаткуллин.

ПОРФИ'РА *и.* Тантаналы вакыйгалар вакытында патшалар кия торган җете кызыл төстәге киң озын ябынча (мантия).

ПОРХУ *ф. диал. к.* порхылдау. *Төтен порхып чыгу.* □ *„Инде бу эш төзәлде“, дип торган чакта, Давылдагы тузан кебек порхып туза.* М. Гафури.

ПОРХЫЛДАТУ *ф. сөйл.* Җыелган кешеләр төркемен куып тарату. *— Туктале, порхылдатып килим әле мин аларны!* Н. Фәттах.

ПОРХЫЛДАУ *ф.* Ургылу, бөтерелү (төтен, тузан һ. б. ш. турында). *Порхылдап төтен чыгу.* □ *Күн ишектән порхылдап тузан очты.* Н. Фәттах.

ПО'РЦИЯ *и.* Берәр нәрсәнең билгеле микъдары, өлеше. *Бер порция шикәр. Бер порция солы.* □ *— Тәмәкем бар. Мин бүтән вакытта үз порциямне иптәшемә бирә торган идем.* Н. Дәүли. || Ашханәләрдә, ресторанларда бер кешегә исәпләп бирелә торган ашамлык яки эчемлек. *Ак алъяпкыч бәйләгән бер бала боларның яныңдагы өстәлгә --- бер порция пәрәмәч китереп куйды.* Ш. Мөхәммәдев. *— Берничә порция тавык ите дә алып килгән идем...* М. Хәсәнов.

ПО'РЦИЯЛЕ *с.* Ашханәләрдә, ресторанларда махсус, индивидуаль заказ белән хәзерләнә торган. *Порцияле ашамлыклар.*

ПОСЁЛОК *и.* Гадәттә шәһәр яки зуррак авыл тирәсендә урнашкан, шәһәр тибындагы зур авыл. *Нефтьчеләр посёлогы. Эшчеләр посёлогы. Шәһәр тибындагы посёлок.* □ *Далада яңа посёлоклар салына.* А. Әхмәт.

ПОСКЫН *и.* Берәр урында яшеренеп, дошманга һөҗүм итәргә әзер торган кечкенә отряд; засада. *[Бурман:] Шушы номер аларга бүген качу оештырган. [Гейфель:] Әһә, сез шуны белеп, анда поскыннар куйдыгыз?* Н. Исәнбәт. *Поскын яуны постырыр.* Мәкаль.

ПОСЛА'ННИК *и.* Башка бер илгә җибәрелгән һәм илчедән бер дәрәҗәгә түбән булган дипломатик вәкил.

ПОСО'БИЕ *и.* Кемгә дә булса ярдәм йөзеннән дәүләттән бирелә торган акча. *Күп балалы аналарга бирелә торган пособие.* □ *Бәхетсезлеккә очраган [кешегә] пособие [бирергә кирәк].* А. Шамов. *Авыл советына ниндидер йомыш белән барган идем. Дилбәрнең пособие акчасын алырга иде бугай.* Э. Касыймов.

ПОСТ *и.* **1.** Берәр нәрсәне саклый, каравыллый яки күзәтә торган урын. *Постта тору.* □ *Сакчылар, начальник белән саубуллашып, үз постларына киттеләр.* Г. Гобәй. *Бер генә минутка да --- постын ташламады [Зәки]. Үзенең пушкасыннан дошман өстенә бер-бер артлы снарядлар яудырып торды.* Р. Ишморат. || Тимер юлларда поездлар хәрәкәтенең куркынычсызлыгын тәэмин итә торган сигналлар һәм рельс күчергечләр белән идарә итә торган урын, будка.

2. Билгеле бер урында берәр нәрсәне күзәтү яки каравыллау, саклау өчен куелган кеше яки кешеләр төркеме. *Шәрифҗан белән Федюшкин --- иген амбарлары яныңдагы постларны тикшерергә Идел буена төшеп киттеләр.* И. Гази. *— Шәһәрдән килдем, беркем дә мине туктатмады. Үткән юлы да постларыгыз ятып йоклаган иде.* А. Гыйләҗев.

3. Җаваплы урын, җаваплы эш. *Завод директоры посты. Җитәкче пост.* □ *Ипташ Шәһәретдинов --- Башгизның җаваплы редакторы булып, матбугат өлкәсендәге [җитди] бер постта җитәкчелек вазифасын үти.* М. Җәлил.

◇ **Постка басу** — үз вазифаларын, үзенә йөкләнгән эшне, үз бурычын үти башлау. *Бу бер төркем гади кешеләр --- үзләренең тәннәрен, җаннарын, ялкынлы йөрәкләрен, туган илләренә тирән мәхәббәтләрен корал итеп, авыр постка басканнар.* Г. Бәширов. **Постта үлү** — үз өстенә йөкләнгән вазифаларны үтәгән вакытта һәлак булу.

ПОСТА *с. диал.* Иясез калган, буш, кеше тормый торган. *Поста йорт. Поста урын.* || *рәв.* Буш, кешесез. *— Катюшасын Байтирәккә озатсын иде. Йорты поста тора бит.* Г. Бәширов. *Аның поста яткан*

йортын бер төн эчендә ремонтлап бир[гәннәр]. Г. Ахунов.

ПОСТАЛЫК *и. диал.* Кеше тормау, буш булу (йорт турында). [*Зиннәт*] *каршы алырга ата-анасы югын да, йортының посталыгын, үзенең ялгызлыгын да уйлап, йөрәге сыкранып китте.* Г. Бәширов.

ПОСТАМЕНТ *и.* **1.** Һәйкәл, колонна, статуя нигезе булып хезмәт итә торган күтәренке урын; пьедестал. *Агачлар астында, яңгырдан ышыкланган шикелле, гади генә постаментта бакыр бюст — һәйкәл тора иде.* Ш. Маннур. *Фәннәр академиясе алдындагы бакчада, биек постаментта башын түбән иеп утыручы Лобачевский яшел яфраклар эченә күмел[гән].* Г. Ахунов.

2. Музейда, күргәзмәдә таш сын астына куела торган бүкән; аскуйма.

ПОСТАУ *и.* Уң ягы киез сыман катламлы йон яки ярым йон тукыма; сукно. *Кунак хатын: „Менә бу эткәйгә", — дип, дүрт аршин постау чыгарды.* Г. Ибраһимов. *Бүлмә уртасында --- урта зурлыктагы, яшел постау ябыштырылган язу өстәле тора.* Э. Еники. || *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Өстенә постау җилән --- кигән, кыска чалбарлы, ак сакаллы мәһабәт кеше тарантастан төш[те].* К. Тинчурин. [*Офицерларның*] *өсләрендә зәңгәр постау шинель.* Г. Гобәй. || *и. мәгъ. сөйл.* Шундый тукымадан тегелгән кием. *Безгә кодачалар килгәннәр. Барысы да постау кигәннәр.* Җыр.

ПОСТАУЧЫ *и.* **1.** Постау туку белгече.

2. Постау белән сату итүче кеше.

ПОСТАШ *с. һәм рәв. диал. к.* поста. *Аның посташ яткан йортын бер төн эчендә ремонтлап бирүләре --- [Дияровның] юл мәшәкатьләрен, кайгы-борчуларын оныттырып җибәргән.* Г. Ахунов.

ПОСТАШЛЫК *и. диал.* **1.** Посташ булу.

2. Бушлык. *Ида почмагындагы посташлык бигрәк тә күзгә нык ташланып тора.* Н. Фәттах.

ПОСТПОЗИТИВ *с. лингв.* Үзе караган яки үзе буйсынган сүз яисә җөмлә кисәге артыннан ук тора торган (мәсәлән: *бара **ич**, синең **белән**). Постпозитив кисәкчә.* □ *„Дллә" кисәкчәсе --- постпозитив позициядә дә килә ала.* Д. Тумашева.

ПОСТПОЗИ'ЦИЯ *и. лингв.* Берәр сүз яки җөмлә кисәге үзе караган сүз яки җөмлә кисәге артыннан ук тору (мәсәлән: *урам **аркылы**, укыгач **ук**).*

ПОСТСКРИ'ПТУМ *и. кит.* Хат азагына кул куйганнан соң өстәп язылган язу (гадәттә бу язу алдыннан латинча P. S. хәрефләре куела). [*Ул*] *аска, постскриптум аша, түбәндәге сүзләрне дә өстәп куйган иде.* Ф. Хөсни.

ПОСТУЛАТ *и. кит.* Исбатланмаган яки дәлилләнмәгән булуына карамастан, дөрес дип кабул ителгән башлангыч, нигез положение. *XIX йөзнең беренче чирегендә дә әле геометриянең нигезендә, элеккечә, Эвклидның ирекле рәвештә, исбат ителмичә генә кабул ителгән башлангыч раслаулары — постулатлары* [*ята*]. Ж. Тәрҗеманов.

ПОСТЫРМА *и. бор.* Берәр җирдә яшеренеп һөҗүм итәр өчен дошманны сагалап торган кеше яки кешеләр төркеме; поскын. *— Бар халыкны минем янга саклык белән җыегыз. Шымчы Армайлар сизмәсен. Постырмалар куегыз.* Т. Гыйззәт.

ПОСУ *ф.* **1.** Кешеләргә, хайван-кошларга күренмәс өчен берәр җиргә, берәр нәрсә артына, эченә яшеренү, качу. *Курыкмадым, тик ул күрмәсен дип, Кереп постым куак астына.* Ф. Кәрим. [*Күгәрчен*] *тиз генә бер авыл янындагы читән арасына кереп посты.* Г. Тукай. || Берәр нәрсә эченә яки артына яшеренү (табигать күренешләре, җансыз нәрсәләр турында). *Каеннар арасына кереп поскан агач йортларны --- кар күбәләкләре сырып алган.* К. Нәҗми. *Кояш инде күптән тауга поскан.* М. Җәлил. *Землянкага кергәч тә, Газинур --- шырпы сызды. Караңгылык почмакларга посты.* Г. Әпсәләмов.

2. Кешегә яки берәр җанлы-җансыз нәрсәгә сыену. *Күкрәгемә поскан ач сабыем: „Әттә", — ди дә төбәлә яшенә.* Н. Исәнбәт.

3. *рәв. мәгъ.* **посып.** Якын-тирәдәгеләргә яки үзе якынлашкан кешегә, җанлы нәрсәгә күренмәскә тырышып, сиздермичә, яшеренеп. *Акбүз посып кына килде дә [шикле кешенең] арт сыйрагыннан каптырып алды.* Г. Гобәй. *Эх сез! Өйрәтермен посып шулай сүзне тыңларга!* Ш. Мөдәррис.

4. *рәв. мәгъ. күч.* **посып.** Бер читтә, кеше күзенә күренмәслек урындарак сүзгә катнашмыйча. *— Әйдә, улым, ояльма, ояльма, әй бәбкәм, песи баласы шикелле посып кына, оялып кына тора.* Г. Камал. || Кешеләр белән бик аз аралашып яки бөтенләй аралашмыйча. *Майпәрвәз ханым, --- киявен бер барып күргәч, чыннан да вакытлыча посып, тынып торуны үзе өчен хәерлерәк булыр дип тапты.* Ә. Еники.

ПОСЫ'ЛКА *и.* Почта аркылы кая да булса җибәрелә торган яки кайдан да булса алынган төргәкле, тартмалы, зур бәйләмле әйбер. *Госпитальдә яткан чагында Нуруллин беркөнне бер хат һәм кечкенә генә посылка алды.* А. Шамов. *Посылкадан чиккән сөлгеләр, күлмәкләр, яулыклар, пима, бияләй һәм башкалар чыга.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Шундый әйберләр кабул итү яки тапшыру белән шөгыльләнә торган. [*Сәлим*] *почтаның посылка бүлегенә атылып барып керде.* Г. Гобәй.

ПОСЫНУ *ф. к.* посу. *Тавышлар якынлаша. Рәүф шаярып бер читкә посына.* Ә. Фәйзи. *Бикбулат калын кашларының бөркәве астында посынган кечкенә күзләре белән идәнгә текәл[де].* Г. Бәширов.

ПОСЫРУ *ф. диал.* Яшерү, качыру; читкә тайпылу, сыгылу. *Агачлар, җилнең теңкә корткыч дәртеннән котылу мәсәсы эзләп, башларын әле бер якка, әле икенче якка посырырга азапландылар.* А. Гыйләҗев.

ПОТ I *и.* Метрик система кертелгәнчегә кадәр кулланылган һәм 16,3 килограммга бәрабәр булган иске авырлык үлчәү берәмлеге. *— Без быел үзебезнең бодай җиреннән йөз кырыгар пот ашлык алырга торабыз.* Г. Бәширов.

◇ **Поты белән** — бик күп, бик зур, чикләнмәгән күләмдә; күпме кирәк — шулкадәр. *Яз булгач, мәхәббәте дә поты белән инде.* Ф. Хөсни. **Поты бер тиен** — 1) бик арзан, бик юнь. *Кабак бик зур да, поты бер тиен.* Мәкаль; 2) кирәкмәс, кирәге юк, кирәге булмаган; әһәмиятсез, әһәмияте булмаган. *— Бик кирәгең бар иде! Синең кебекләрнең поты бер тиен.* Т. Гыйззәт. **Потка тулмаган** *хурл.* — тиле-миле яки җинел холыклы кеше турында әйтелә. *— Мин сиңа карап торам-торам да исем китә: әллә инде син азрак потка тулмаган, әллә мин үзем акышмакышрак...* Ф. Бурнаш.

ПОТ II *и.* Борынгы төрки халыкларда табыну өчен ясалган һәм ислам дине кабул ителгәнчегә кадәр алла урынына йөртелгән кеше кыяфәтле таш сын; балбал, санәм. *Шәрык илләрендә төрле потларга табынучы кайбер татар халыклары безнең телебездә сөйләшләр.* Х. Фәезханов. *Табынмам „пот"ларыңа, Түгел бит ул минем аллам.* Б. Рәхмәт.

ПОТАШ *и.* Үсемлек көленнән, хлорлы калийдан табыла торган ак порошоктан гыйбарәт селтеле матдә. *— Син, апай кеше, [сабынны] аның эченә салынган сода яисә поташ белән генә ачы дип беләсеңме?* Ә. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Шундый матдә ясый торган. [*Ул*] *авылда поташ заводы ача.* Каз. утл.

ПОТЕНЦИАЛ *и.* **1.** *физ.* Берәмлеккә тигез булган уңай корылманы чиксезлектән кырның билгеле бер ноктасына күчергәндә эшләнгән эш микъдары белән үлчәнә торган зурлык. *Потенциаллар аермасы. Тарту көче потенциалы.* □ *Инженер электр потенциалын тикшерде.* А. Тимергалин.

2. *күч. кит.* Берәр максат белән файдаланыла торган чаралар җыелмасы; берәр нәрсәнең көч-куәт дәрәҗәсе. *Дәүләтнең экономик потенциалы. Промышленность потенциалын сугыш максатларында куллану.* □ *Совет Россиясе һәм аның союздашларының хәрби потенциалы Германиянең һәм аның союздашлары Япония белән Италиянең хәрби потенциалларыннан артыграк.* Каз. утл.

ПОТЕНЦИАЛЬ *с. кит.* Потенциядә булган, потенциядә саклана торган, яшерен, эчке. [*Революция*], *адәмнәр тормышының иң төпкә катлауларынача төшеп, гади вакытта күзгә күренмәгән потенциаль көчләрне тартып чыгара.* Г. Нигъмәти. *Саламда туклыклы органик матдәләр күп, шуңа күрә аның потенциаль энергиясе туклыклы азыкларныкы кадәр үк.* А. Расих. || Булуы ихтимал, мөмкин булган. *Потенциаль дошман.* □ *Потенциаль җинаятьче булуы аның бөтен кыяфәтенә чыккан!* А. Гыйләҗев.

Потенциаль энергия *физ.* — җисемнәрнең яки бер җисем кисәкчекләренең үзара торышларына карап билгеләнә торган энергия.

ПОТЕНЦИРЛАУ *ф. мат.* Бирелгән логарифм буенча санны табу (логарифмлауның киресе).

ПОТЕ'НЦИЯ *и. кит.* Моңарчы яшеренеп яткан һәм билгеле шартларда гына хәрәкәткә килә торган көч, сәләт, мөмкинлек. *Бу ягымлы, кешелекле* [*Дэвиста*] *без Джонсоннарга каршы көрәш потенциясенең һәр көн үсә баруын күрәбез.* Н. Юзиев. [*Ш. Шамильскийда*] *башта ук гажәп зур иҗат потенциясе ачыла, һәм ул үзенең иҗатында бертуктаусыз үсә, ныгый, камилләшә бара.* Ә. Еники.

ПОТЛАП *рәв.* **1.** (Ярты, ике, берничә һ. б. ш.) пот I авырлыгында, пот үлчәве белән, потлар санынча. *Итне кадаклап, онны ярты потлап ала торган кеше хәзер тәмам күтәрелде.* Ш. Мөхәммәдев. || Саннар янында чамалыкны белдерә. — *Безнең җирдән биш мең потлап бодай чыгарга тиеш.* Г. Бәширов.

2. *күч.* (Гадәттә кабатлаулы формада: **потлап-потлап.**) Күпләп, күп итеп. — *Тәкъдир минем башыма бәлане потлап-потлап яудырырга карар биргән икән.* Г. Камал.

ПОТЛЫ *с.* **1.** Потлап үлчәнгән. *Потлы он.*

2. Пот I авырлыгында булган, пот тарта торган. *Хәлим үлчәүдән сикереп төште дә идәндәге ике потлы гергә килеп ябышты.* И. Гази. — *Менә син шушылай ике потлы йөк күтәр.* Г. Бәширов. || Пот I сыешлы. *Потлы чиләк.* □ *Нәҗип чын солдат капчыгын --- үзгынчыдан үзләренең биш потлы яңа киндер капчыкларына алыштырып алды.* Г. Гобәй.

ПОТЛЫК *с.* Пот I авырлыгында булган, пот тарта торган. — *Минем иптәш алты потлык сабын кисмәген күтәреп илткән җиреннән сөртенеп егылды.* Ә. Фәйзи. || Бер пот I керешле, сыешлы.

ПОТ-ПОТ *рәв. к.* потлап. *Казнамнан ал пот-пот көмеш-алтын.* Г. Тукай.

ПОТХАНӘ *и. бор.* Мәҗүсиләр потка II табына торган кечерәк изге бина. *Йосеф илә потханәгә ул бик керде.* К. Гали.

ПОТЧЫ *и.* Һәр көн бер пот сөт савучы.

ПОФФ *аваз ияр. к.* пуф. [*Миңсылу*] *сулаганда һаваны борын аркылы эчкә тарта да ябык иреннәре аркылы пофф иттереп озайтып чыгарып җибәрә.* Ш. Камал.

ПОФЫЛДАУ *ф. диал. к.* пуфылдау. — *Миңсылу, нишләп болай пофылдыйсың?* Ш. Камал. — *Гафу үтенәм, яшьләр,* — *диде* [*юан ир*] *пофылдап,* — *кунагымны җуйдым.* Г. Әпсәләмов.

ПОХОД *и.* **1.** Гаскәр яки оешкан отряд, нинди дә булса бурычны үтәү өчен, бер урыннан икенче урынга күчү. *Рота ике минуттан походка чыга.* Г. Гобәй. *Гаскәр походка җыена.* М. Җәлил.

2. *с. мәгъ.* Шундый күчүләрдә була торган, шундый күчүләргә хас. *Поход тәртибе. Поход тормышы. Поход җыры.* □ *Оркестрлар уйный поход маршын, Ике яклап халык тезелгән.* Ә. Исхак. *Бәйрәм көннәрендә күзем алмыйм Поход колоннасы өстеннән.* С. Хәким. || Шундый күчүләр өчен махсус билгеләнгән яки хәзерләнгән. *Поход палаткасы.* □ *Немецларның сугыш өчен махсус алдан әзерләп куйган поход икмәге --- таш кебек каты.* Ә. Еники. || Хәрәкәттәге гаскәр яки экспедиция белән бергә була торган, бергә йөри торган, күчмә. *Поход радиостанциясе. Поход лазареты.* □ *Поход кухнясыннан күңелле генә булып зәңгәрсу төтен бөркелеп чыга.* А. Шамов. *Чокыр эче бик тиз хәрби поход мастерское төсенә керде.* Г. Гобәй.

3. *сөйл.* Берәр гомуми максат белән оешкан рәвештә кая да булса бару. *Кинога коллектив поход оештыру. Туристик поход.*

4. Берәр илгә яки халыкка каршы алып барыла торган сугыш хәрәкәтләре. *Рим папасы --- Советларга поход ясау өчен Җыймак була дошман төркемен.* М. Гафури.

5. *күч.* Берәр максат белән кемгә яки нәрсәгә дә булса каршы (яисә аларны яклап) чыгу. *Буржуаз матбугатның Совет иленә каршы походы. Экономия өчен поход.* □ *Язучының Донбасска килүен бер культура походына, шахтёрларны әдәбиятка якынайту кампаниясенә әйләндерүләре — бу шахтёрларның пролетариат язучылары алдында үзләренә кирәкле әдәбиятны сора[вы] - -- түгелме?* Һ. Такташ. [*Эшсезләр*] *эш эзләп тә, эш тапмыйча, Айлар-еллар эшсез йөриләр. Бу тормышка протест йөзеннән Ачлык походлары ясыйлар.* М. Гафури.

Поход йөрү — билгеле бер максат белән бер урыннан икенче урынга оешкан төстә күчеп йөрү. — *Күзләрең дә снайпер күзләре кебек үткен, аяклары да поход йөрерлек кенә.* А. Әхмәт. **Поход чыгу** — берәр төрле бурычны үтәү, максатка ирешү өчен икенче бер урынга күчә, бара башлау (оешкан кешеләр төркеме турында). *Поход чыктык таң алдында, Кулда, билдә кораллар.* Бәет. *Таң белән пионерлар инеш буйлап поход чыга.* Г. Гобәй.

ПОХОДЧЫ *и.* Походта катнашучы кеше. [*Айбулатов*] *походчыларны зур юлга чыгулары белән котлады.* Г. Ахунов.

ПОХ-ПОХ *аваз ияр.* Басым астында өзек-өзек һава, газ яисә пар чыкканда була торган ярым шартлаулы тавышны белдерә.

Пох-пох итү (килү) — шундый тавыш чыгару. [*Бүген*] *завод-фабрика биналарының кабыргаларыннан һәрвакытта пох-пох итеп өзек-өзек ак пар чыгарып торган тын юллары эштән тукталганнар иде.* М. Гафури.

ПОХЫН *и. диал. мыск.* Симезлектән өзек-өзек авыр тын алучы, үз-үзен көчкә күтәреп йөрүче кеше яки хайванга карата әйтелә.

ПО'ЧЕРК *и.* **1.** Һәркемнең үзенә генә хас булган язу рәвеше. *Балалар почеркы. Почеркларны чагыштыру.* □ *Конверт тышындагы почеркны күрү белән аның йөрәге дөп-дөп итеп тибә башлады: „Вәсимә кулы бит бу“,* — *диде.* Г. Галиев. *Комиссия бандит әмирҗан янында табылган* [*исемлекне*] *Нәгыйм почеркына туры килми дип таба.* Ш. Камал.

2. *күч. сөйл.* Берәр нәрсәне эшләү, ижат итү рәвеше; берәр эш башкарганда, ижат иткәндә ачык чагыла торган характерлы үзенчәлекләр җыелмасы, язу стиле. *Ул үзенә бер төрле дхмәт. Биографиясе белән дә, кеше буларак та, иҗади юлы һәм әдәби почеркы ягыннан да.* Ф. Хөсни. [*Укучыларның*] *язучыны, үзен күрмичә дә, китабы, язу ысулы, әдәбиятчылар теле белән әйтсәк, почеркы аркылы тануларын да без иҗат тәҗрибәбездән дә күптән беләбез.* Г. Минский.

ПОЧЁТЛЫ *с.* 1. Аеруча хөрмәт йөзеннән сайлана, бирелә торган. *Почётлы президиум. Почётлы граждание.* □ — *Сезне, Ислам абый, безнең оешманың почётлы пионеры итеп кабул итәбез.* Каз. утл.

2. Хөрмәт билгесе булып санала торган, хөрмәт йөзеннән оештырылган. *Такташ гәүдәсе янында язучылардан, артистлардан, студентлардан һәм эшчеләрдән почётлы каравыл торды.* Х. Сәлимҗанов.

ПОЧКАК *и. диал.* Киң нәрсәнең кечкенә бер өлеше, кисәге. [*Гыймран*] *кара җеп белән бер кара почкак сорап алды, ике җиң очына да тигез итеп ямау салып чыкты.* Ш. Маннур. *Сибайның җирән бөдрә чәчләрен, өй түбәсендәге бер почкак саламны селкеткән кебек, өзлексез җил җилбердәтә.* А. Гыйлаҗев.

ПОЧМАК *и.* 1. Предметның ике ягы кисешә торган урын. — *Ишектән генә керим дисәм, өй почмагыннан бер кеше килеп чыкты.* Г. Камал. *Кабернең дүрт почмагына дүрт кеше утыр[ган].* М. Гафури. || Ике урам кисешә торган урын; чат. *Көфер почмагы. Урам почмагы.* □ — *Әфләтуннар почмагында күп кешеләр җыелып сөйләшеп тора.* М. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Урам чатындагы. *Бакау олы урам юлыннан елга урамына борылганда, почмак йорттан бер төркем халык чыкты.* А. Таһиров.

2. Эче куыш предметның ике стенасы эчке яктан кисешкән урын. *Бүлмәнең ике почмагында зур-зур яшел сандыклар өстенә кат-кат түшәкләр өелгән.* Ә. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Шундый урынга урнашкан. *Ул, үз янындагы почмак өстәлгә таянып, башын бераз вакытка ике кулы белән кысып торды.* Ф. Әмирхан.

3. Берәр яссы әйбернең ике ягы кисешкән урыны, чите. *Өстәл почмагы. Яулык почмагы.* □ [*Кәгазьнең*] *сул почмагында бик үк ачык төшмәгән штамп иде.* Ә. Еники. *Мәйданның бер почмагында дегет төсле кара төтен зәңгәр һавага үрел[ә].* А. Алиш.

4. *күч.* (Күңелдә, йөрәктә) беркемгә дә белгертми, сиздерми, тирән сер итеп сакланган урын. *Бу сүзләр аларның йөрәкләренең иң нечкә почмакларына барып утырды.* Ш. Усманов. *Аның болай --- күз көвеге булып йөрүеннән котыласы килү теләге күңеленең яшерен бер почмагында торган кебек була.* М. Гафури.

5. *диал.* Авыл өйләренең такта яки чаршау белән бүленеп алынган кечкенә ягы, аш-су хәзерли торган мич алды ягы. *Сафия абыстай бер почмакка кереп, бер түргә чыгып, ара-тирә сүзгә дә кушылгалап китә.* А. Шамов. — *Мин, почмакка чыгып, ястү намазы укып алырмын.* М. Гали.

6. Мәктәптә, учреждениеләрдә: һәртөрле түгәрәкләр, өйрәнүләр, тикшеренүләр алып барыла торган махсус урын, бүлмә. *Беренче класслар табигать почмагында ике әрҗәгә кабак утырталар.* Г. Гобәй. *Кызыл почмак --- матур итеп җыештырылган.* А. Алиш.

7. Бүлмәнең хак түләп вакытлыча файдалануга бирелә торган өлеше. *Читтән торып укучы студентлар өчен почмаклар кирәк.* Соц. Тат. || Өйнең, квартираның, бүлмәнең берәр кешегә билгеләнгән, берәр кеше шөгыльләнә торган өлеше. *Балалар почмагы. Эш почмагы.* □ *Бәлки, берәрсе, картлыгына хөрмәт йөзеннән, аны үз йортына алып, аерым почмак бирер, кадерләп асрый торгандыр.* Г. Ибраһимов. || (Гадәттә *„үз“* сүзе янында). Яшәр, көн итәр урын. *Миңнурый ятимлектә үсте, аның үз өе, үз почмагы булмады.* Г. Әпсәләмов. *Дөрес, өй инде искесен иске, --- [ләкин], нәрсә генә әйтсәң дә, вакытлы гына булса да, үз почмагың, үз оян.* А. Шамов.

8. *күч.* Үзәктән бик ерак, читтәге як, урын, төбәк. — *Эләктерсәләр инде, [жандармнар сине] Енисейгә генә озатмаслар, Якутстанның ерак, караңгы почмакларына ташларлар.* Г. Ибраһимов. *1905 елгы революция дулкыннары шушы тын гына почмакны да читтә тын гына калдырмый.* Ш. Камал. || Шәһәр, ил һ. б. ш. ның читтәге бер өлеше, районы, төбәге, урыны турында. *1929 елда булган соңгы юбилее уңае белән [Г. Камалга] Советлар иленең төрле почмакларыннан хатлар һәм телеграммалар килә.* М. Гали. *Махно бандасы Украинаның төрле почмакларында аерупча активлык күрсәтергә тотынды.* А. Шамов.

9. *жарг. иск.* 25 сумлык купюра яки 25 сум акча. [*Гыймади кулын сузып:*] *Почмак яряймы?* [*Гайфулла, Гыймадины этеп җибәреп:*] *Нәрсә, сорамас борын хак бирәсең?* К. Әмири. — *Әмма мөгәричен дә инде чамасыз сорыйсың. Ике пальтога бер почмак җитмәгәнмени?* М. Мәһдиев.

10. *мат.* Бер ноктадан чыккан ике туры арасындагы яссылык. *Почмак үлчәү. Туры почмак (90°). Кысынкы почмак. Җәенке почмак. Авышлык почмагы. Тиңдәш почмаклар. Эчке почмак.* □ *Бу почмакның зурлыгы С ноктасының АВ га кадәр булган ераклыгына бәйле.* Ж. Тәрҗеманов. *Бушуев аударган агачларның башлары барысы бер юнәлештә трактор юлының ике ягына почмак ясап яталар.* Г. Әпсәләмов. || *махс.* Берәр нәрсәне үлчәү берәмлеге буларак бер ноктадан чыккан ике сызыкның үзара авышлык дәрәҗәсе. *Почмак градусы.*

11. *рәв. мәгъ. күч.* **почмактан.** Хыянәтчел, астыртын, яшерен рәвештә, качып-посып (ату, үтерү, һөҗүм итү турында). *Аның өчен бик күп кыюларны үтерделәр качып почмактан.* Ә. Исхак.

Почмак биссектрисасы *мат.* — почмак түбәсеннән аны урталай бүлеп үткән туры. **Почмак түбәсе** *мат.* — почмак төзи торган ике туры сызык кисешкән нокта. **Почмак урталыгы** *мат. иск.* — *к.* биссектриса. **Почмактан сугу (бәрү)** — футбол уенында: футбол кырының бер почмагыннан түпкә тибү.

◇ **Почмакка кую (бастыру)** — балаларны почмак җиргә стенага каратып бастыру (җәза бирүнең бер төре). — *Кичә Валерик Реваны этеп екты. Аны почмакка бастырдылар.* Г. Минский.

ПОЧМАКЛАНУ *ф.* 1. Почмак хасил булу, почмаклы булу. *Солдат, бу сүзләрне әйткәндә, күзләрен почмакландырып* [*йөкл. юн.*], *күбрәк мәгънә аңлатырга тырыша.* Ш. Камал.

2. *күч.* „Дәрт“, „күнел“ сүзләре белән килгәндә: тулысынча канәгатьләнү, күнел булу. *Бара торгач, Гәрәйнең дәрте почмакланды: аучылык хирыслыгы сүрелде.* А. Гыйлаҗев. | *и. мәгъ. Сеңелесенең булдыклылыгыннан Бибиҗамал апаның күңеле ни дәрәҗәдә почмаклануын күз алдына китерүе читен булмаса кирәк.* Ш. Хөсәенов.

ПОЧМАКЛАУ *ф.* Почмак хасил итү, почмак рәвешенә китерү, почмак ясау. *Почмаклап кисү.*

ПОЧМАКЛЫ *с.* Күпмедер, ниндидер почмагы булган, (бер яки берничә) почмактан торган. *Сиксән биш сумга югары оч Галәвинең алты почмаклы өен алдык.* Г. Ибраһимов. *Сәлим кыюсызланып кына дүрт почмаклы өстәлнең бер читенә килеп утырды.* Г. Гобәй. || Почмакланып килгән, почмаклап эшләнгән.

ПОЧМАКЛЫК *и.* 1. *мат.* Саннар яки кайбер сыйфатлар белән кушма сүзләр тәшкил иткәндә: билгеле

бер сандагы яки рәвештәге почмаклары булган геометрик фигура. *Алты почмаклык. Кысынкы почмаклык.*

2. *махс.* Почмаклар сызу, перпендикулярлар үткәрү өчен өчпочмак рәвешендәге сызым коралы; *русчасы:* угольник. *Сантиметр, кайчы, почмаклык, булавкалар[дан] --- башка үлчәү алырга мөмкин түгел.* Һөнәрленең кулы алтын.

3. *махс.* Төзү эшендә почмакларны сызу һәм үлчәү өчен кулланыла торган җайланма; *русчасы:* малка.

ПОЧМАКЛЫ-ТҮРЛЕ *рәв. диал. к.* ишекле-түрле.

ПОЧМА'КЧА *с. мат., физ.* Почмак (1, 10 мәгъ.) үлчәүгә бәйләнешле. *Почмакча коэффициент.*

Почмакча тизлек *мат.*— әйләнүче ноктаны әйләнү үзәгенә тоташтырган радиусның билгеле бер вакыт берәмлеге эчендә ясаган почмагы белән үлчәнә торган зурлык. **Почмакча тизләнеш** *мат.* — әйләнмә хәрәкәттәге җисемнең почмакча тизлегенең билгеле бер вакыт берәмлегендә үзгәреше белән үлчәнә торган зурлык.

ПО'ЧТА *и.* 1. Хатлар, посылкалар, акча, вакытлы матбугат һ. б. ш. ны бер җирдән икенче җиргә җибәрә яки кабул итә торган әлемтә учреждениесе; шул учреждение урнашкан бина яки бүлмә. — *Хат саласым бар икән, онытканмын, мә шуны почтага салып кайт әле.* Ф. Сәйфи-Казанлы. — *[Сиңа] посылка. Почтадан барып ал.* Г. Гобәй. || *җый.* Шундый әлемтә учреждениеләре системасы. *Почта аша хат җибәрү. Хәрби почта.* □ *Губернатор тарафыннан бирелгән әмер буенча, почта илә килгән хатларны полиция ачып[а].* Ш. Мөхәммәдев.

2. *с. мәгъ.* Хатлар, посылкалар, газета-журналлар һ. б. ш. ны тарату, җибәрү белән бәйле. *Почта маркасы. Почта открыткасы. Почта расходлары. Почта кәгазе.* □ *Почта бүлегендә аңа бер пакет китереп бирделәр.* Г. Бәширов. || Берәр җиргә җибәрелә торган хатлар, бандерольләр салу өчен махсус куелган, билгеләнгән. *Хат кулын пешерә кебек тоела аның. Ахырда ул аны почта ящигына илтеп сала.* И. Гази. || Шул учреждениедә хезмәт итә торган. *Почта хезмәткәре.* □ *Почта агенты колхозга һәр көнне бер кочак газета китара.* Г. Гали.

3. Шундый учреждениеләр тарафыннан берәр җиргә җибәрү яки илтеп тапшыру чарасы. *Һава почтасы. Атлы почта.* □ — *Почтадыр әле, тарантас җиккән.* Г. Гобәй. || Хатлар, посылкалар, акча һ. б. ш. корреспонденциянең чираттагы җибәрелеше яки илтеп тапшырылышы. *Кичке почта китергән хат һәм газеталарны кулыма алам.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Хатлар, посылкалар һ. б. ш. нәрсәләр җибәрү, илтеп тапшыру өчен билгеләнгән. *Почта самолёты. Почта вагоны.* □ — *Атыгыз үзен. Ат. Почта күгәрчене* [ул]. Н. Исәнбәт.

4. *сөйл.* Шундый учреждениеләр тарафыннан китереп тапшырылган нәрсә (хат, посылка, газета-журнал һ. б. ш.); корреспонденция. — *Почтаны алган чагында хатларны аерым бер газетага төреп куегыз.* Ш. Камал. *Латиф өстәлендә яткан бүгенге почтаны караштыргалады.* А. Расих.

5. *тар.* Хатларны, посылкаларны һ. б. ш. ны җибәрү һәм кабул итүдән тыш, атлы экипажларда даими рәвештә пассажирлар йөртү белән шөгыльләнгән әлемтә учреждениесе. || *с. мәгъ.* Элемтә учреждениеләре ведомствосы карамагында: атлы экипажларда даими рәвештә пассажирлар йөртү белән бәйле. *Почта каретасы. Почта станциясе.* □ — *[Артамонов] почта атларына утырып качты.* Т. Гыйззәт.

Почта йөртү — һәртөрле хатларны, посылкаларны һ. б. ш. әйберләрне ат, машина һ. б. белән берәр почта учреждениесенә яки торак пунктка ташу. *Иван Никитич Казан белән Зөя, Зөя белән Чабаксар арасында почта йөртә иде.* М. Гали. **Почта уены** — 1) күңел ачу кичәләрендә бер-берәнә язган хатларны тышына язган номерлар буенча махсус кеше таратып йөрүдән гыйбарәт уен (һәр кешенең күкрәгенә номер беркетелгән була). *Почта уенында Уфаның иң алдынгы, һәр җәһәттән иң өстен торган бер туташка --- көйле итеп бернәрсә яздым.* Ш. Бабич. *[Хәят] почта уены вакытында килгән хат һәм язуларны кабат-кабат кулга алып укып карый.* Ф. Хөсни; 2) берәр торак пункт исеменең беренче хәрефенә башланган сүзләрне хат ташучыга тукталмый-нитми санап чыгудан гыйбарәт балалар уены.

ПО'ЧТАЛЫ: почталы уйнау — *к.* почта уены (2 мәгъ.). *Менә, мин әйтәм, кызык икән бу почталы уйнау.* Г. Галиев.

ПОЧТАЛЬОН *и.* Хат, газета-журнал һ. б. ш. ны ияләренә (адресатларына) тапшырып йөрүче почта хезмәткәре; хат ташучы. *Почтальон кыз Гөлназ һәр көнне авылга сумкасын тутырып хат ташый, һәр йортка икешәр, өчәр хат калдырып китә.* Н. Дәүли. *Хәмитов ишегендәге ящикка почтальон газеталар төшереп китә.* Г. Минский.

ПОЧТАМТ *и.* Шәһәрнең үзәк почта учреждениесе.

ПОЧТАРЬ *и. сөйл. к.* почтальон. *[Листовкаларны] бу юлы инде үзе белән алмыйча да мөмкин булмады, чөнки легион почтарьларының башкача килү ихтималы юк, ара бик тар калган иде.* Ш. Маннур.

ПО'ЧТАЧЫ *и. сөйл.* Почтада эшләүче кеше, почта хезмәткәре. *Ул котларга килгән монда Почтачылар бәйрәмен.* М. Җәлил.

ПОЧЫК I *и.* 1. *бор.* Ике пот, ике подаука (32 килограмм чамасы); ярты батман. *Батман бирсән, күп булыр; Подаука бирсән, аз булыр; Почык бирсән, тамандыр.* Бәет. *Үзендә — батманы, кешедә — почыгы.* Мәкаль. || Шуның кадәр әйбер сыешлы савыт.

2. *диал.* Кабык чиләк, тубал; зур тырыс.

3. *бор.* Нәрсәнең дә булса яртысы.

4. Кечерәк кисәк, кечерәк өлеш. *[Кояш тотылганда:] Сүнә көнебез [кояшыбыз], Кала бер почык.* Н. Исәнбәт.

5. *диал.* Дисәтинәнең сигездән беренә бәрабәр җир үлчәве.

ПОЧЫК II *с.* Кыска, очы өскә күтәрелгән, курнос (борын турында). *Шул почык борынга мең тапкыр рәхмәтләр әйтәсем килде.* Г. Галиев. *[Кызның] кашлары кара булгандыр инде, авызы кечкенә, борыны почык.* Г. Әпсәләмов.

ПОШАЛАНУ *ф. диал.* Берәр эшне кайгырту, аның хәстәрен күрү, пошыну. — *Хәзер РТС әйтә, председательдән сорагыз, ди. Д Самат бу турыда аз пошалана.* Г. Мөхәммәтшин.

ПОШАМАН *и.* Нык борчылулы, аптыраулы, куркулы, шикләнүле уй. *Сөйләшеп утыра торгач, син күңеледдәге пошаманны әйтмичә булдыра алмадың.* Э. Касыймов. *Шуннан бирле эчкә пошаман төште.* Р. Төхфәтуллин.

◇ **Пошаман салу** — борчуга төшерү, борчулы уйлар тудыру, аптыраша калдыру. *Әллә яратмый микән ул мине хәзер? Аның болай булуы минем эчкә пошаман сала.* Ш. Маннур. **Пошаманга калу (төшү)** — нәрсә эшләргә белми аптырау; борчылу, тынычсызлану, куркуга калу. *„Апа нигә миңа туры карый икән?"— дип пошаманга калдым.* Г. Галиев. *[Егор] кибеттән кәефе кырылып һәм пошаманга төшеп чыкты.* Г. Мөхәммәтшин.

ПОШАМАНЛЫ *с.* Аптыраулы, борчулы, куркулы. *Ышанып иярген кешеләрнең ышанычларын аклый алырмынмы, диңгез яндырырга вәгъдә итүче песнәк хәленә төшмәмме, дигән пошаманлы уй борчый [аны].*

И. Гази. *Колхозчыларның берсе тора да шул пошаманлы хәлне бик оста һәм бары тик халыкта гына табылуы мөмкин булган табигый үткенлек белән әйтеп бирә.* Ф. Хөсни.

ПОШАМАНЛЫК *и.* Борчылу, күңел тынычсызлыгы, аптыраш. *Папкага теркәлгән сводкалар белән танышкач, Садыйковның кәефе, рухы авырая барды. Чыраена уйчанлык, пошаманлык калыкты.* С. Рафиков.

ПОШАМАНСЫЗ *с.* Бернәрсәгә дә борчылмый, аптырамый торган, ваемсыз. *Беренче карашта әмин әкәнә чынлап кайгыра да, борчыла да, хәтта кәефсезләнә дә белмәгән гаҗәп ваемсыз, пошамансыз бер кеше диярсең!* Ә. Еники.

ПОШИ *и.* Боланнар семьялыгыннан күшәүче, имезүче эре хайван (иркәкләренең мөгезләре киң көрәк сыман, тармаклы була). *Ана поши. Поши тиресе. Поши ите.* □ *Сыер шикелле зур гәүдәле һәм көрән йонлы, агач ботагыдай тармакланып торган зур мөгезле поши үзенең матур һәм моңсу күзләре белән балаларга карап тора.* Ә. Фәйзи. *Поши, муенын сузып, башын күтәреп, юлчыларга карады. Аның башы ат башыннан киң һәм зуррак та булыр.* С. Рафиков.

ПОШИМАН *и. диал. к.* пошаман. *Хәдичә түтинең теле пышылдап намаз догаларын укыган булса да, күңеленә тагын пошиман төште: „Ай алла, ул хафалы җанына ни булды инде тагын? Бу вакыт җиткәч, нәрсә исенә төште икән?“* Г. Бәширов. *Хәбирнең эченә пошиман керде. Мондый гадәте булгач, бу самолётның тагын бер тәүлек утыруы мөмкин лә-баса.* Ш. Хөсәенов.

ПОШКУ *ф. диал.* **1.** Тишектән яки ярыктан төтен яисә газ чыгып тору.

2. Сасу, исләнү.

ПОШКЫРТУ *ф.* **1.** *сөйл.* Берәр сыеклык яки газны көч, басым белән бөркү, сибеп чыгару. *Фонтан күленең уртасында мәрмәр бала фәрештә скульптурасы курай аркылы су пошкыртып тора.* Ш. Камал.

2. *күч. гади с.* Кемне дә булса берәр урыннан куу, куып чыгару. — *Патшасы белән берәттән боярларны да пошкыртырга кирәк.* А. Таһиров. [*Фәридә*нең] *ир-атка карата үзен бик усал тота дип сөйлиләр, табагач белән пошкыртып чыгармас микән өеннән?* Ш. Бикчурин.

ПОШКЫРУ *ф.* Борын тишекләрен калтыратып, тавыш белән һава, сулыш чыгару. *Артыбызда ат пошкырганы ишетелде.* Х. Кәрим. *Бобик, борынына чебен кергән төсле, һаман пошкырып ята.* Ш. Камал. || Тавыш белән өзек-өзек һава, газ һ. б. чыгару. *Ул машина үзе һаман пошкыра, тирә-юньне бик тәмсез ис белән тутыра.* А. Алиш. *Трактор да ярсып пошкырды.* М. Җәлил.

ПОШКЫРЫНУ *ф.* Вакыт-вакыт пошкырып кую; үзалдына пошкырып куйгалау. *Пошкырынып атлар уза юлдан.* С. Хәким. *Түп-түгәрәк алашалар пошкырынып вә һәр икесе башларын купшы кәкрәйтеп сикертәләр иде.* Ф. Әмирхан.

ПОШКЫТУ *ф. диал.* **1.** Төтен яки газ чыгарып тору.

2. Сасыту.

ПОШЛАК *с. диал.* Җитлекмәгән, булдыксыз яшь-жилкенчәк; гомумән җитлекмәгән, булдыксыз, пешмәгән кеше (гадәттә *„сары пошлак“* тезмәсендә килә). — *Сиңа бирмиләр бит аны, пошлак! Башың яшь...* А. Гыйләҗев.

ПО'ШЛИНА *и. экон.* Читкә чыгарыла яки читтән кертелә торган товарларга, милекләргә дәүләтнең акча салымы. *Таможня пошлинасыннан казна елына 92 миллион* [*сум*] *файда күр*[*гән*]. Г. Коләхметов. *Бер мәмләкәттән икенчесенә мал кертүне тыгызлый торган пошлиналар* [*бар*]. Урал. || Берәр эшне рәсмиләштерү өчен акча салымы. *Язылышу өчен пошлина. Документ расламу пошлинасы. Суд пошлинасы.* □ [*Түрәләр*] *туйлардан пошлина алырга низам чыгардылар.* Шура. [*Күргәзмәдә*] *яхшы хайванга бик күп пошлина салына, диләр.* Х. Ямашев.

ПО'ШЛИНАЛЫ *с.* Пошлина салына торган, пошлина түләтелә торган.

ПОШМАН *и. сир. к.* пошаман. *Кечкенә дошман зур пошман китерер.* Мәкаль. *Мин аларны көч-хәл белән - - - укыдым да, сезнең Тау яклары әйткәнчә, пошман булдым. Ник дисәң, аларның берсе дә романнарның киртәсенә керү түгел, хәтта ул киртәнең янына да килми иҗ!* Л. Җәлә́й.

ПОШМАС *с.* Бер нәрсә турында кайгыртмый, уйламый, бер нәрсәнең дә хәстәрен күрми торган; ваемсыз, гамьсез. || Шундый халәтне белдергән. *Ул Булатовның үз-үзеннән канәгать булган, иренчәк, пошмас йөзен күз алдына китерде.* Н. Фәттах. || *и. мәгъ.* Шундый кеше. *Үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын, дип караучы пошмасны гына сораулар, уйлар борчымыйдыр.* Р. Фәйзуллин. — *„Ашыгыч ярдәм“ дип, пошмасларны көтеп яткančы, [киттек]!* Б. Камалов.

◇ **Пошмас җан** *сөйл.* — бер нәрсә турында да кайгыртмый, уйламый торган, ваемсыз, гамьсез кеше турында. *Ичмаса, бер-ике машина килеп чыкса, паромдагылар ашыга төшәр иде. Көт менә хәзер ул пошмас җаннарны.* Э. Касыймов. *Кем әйтер аңа пошмас җан дип, Начар хуҗа дияр кем аңа?* З. Мансур.

ПОШМАСЛЫК *и. сөйл.* Ваемсызлык, гамьсезлек. *Газинур аның бу пошмаслыгына эченнән бик нык ачуланса да, тыштан сиздермәде.* Г. Әпсәләмов.

ПОШНАУ *ф. диал.* Пош-пош килү; мышнау. *Лачтыр-лочтыр күшәгән, пош-пошшш... пошнаган сыер тавышыннан башка тавыш юк.* З. Һади. [*Аның*] *пошнаганы да ишетелә иде.* К. Тинчурин.

ПОШ-ПОШ *аваз изл.* Берәр куе массадан һава бөркелеп бүленеп чыкканда, мышнаганда һ. б. очракларда хасил булган тавышны белдерә.

Пош-пош итү (килү) — пош-пош иткән тавыш чыгару. — *Абзый, пош-пош килеп, кибәк ашаган сыер шикелле мышкылдап йөри.* Г. Камал.

ПОШТЫРДАУ *ф. к.* пыштырдау. — *Пошгырдама инде, Габдулла, йокларга ирек бирмисең.* Ф. Әмирхан.

ПОШТЫР-ПОШТЫР *аваз изл. к.* пыштыр-пыштыр. *Шәкерт хәзер икенче көнге дәрес өчен, пошгыр-пошгыр килеп, әллә нинди бәхәсләр бикләп ята.* Ф. Әмирхан.

ПОШУ I *ф.* **1.** Гадәттә *„эч пошу“* тезмәсендә кулланылып, нәрсәгәдер борчылу, сагышлану, тынычсызлану, ямансулау мәгънәсен белдерә. *Пошмыйк әле яшьлек үтә диеп, Туксан бише үтсә, йөз килер.* Г. Афзал. *Ялкау часовой да пошмый гына ятып йоклаган.* М. Җәлил. || Гомумән берәр нәрсә турында кайгырту, борчылу. *Аларга ни, үгез үлсә — ит, арба ватылса — утын, ай-һайларында да юк, пошмыйлар да ичмасам.* Н. Фәттах.

2. *и. мәгъ.* Күнелсез, сагышлы уй яки халәт; пошаман. *Бабайның үзенә дә пошу керде.* Л. Хәмидуллин.

ПОШУ II *ф. диал.* Пычак белән сыдырып җибәрү.

ПОШЫГУ *ф.* Эштән борчылу, кайгыру. *Бирергә ашыкма, пошыкмассың.* Мәкаль. *Үгез җиксәң — ашыкма, җай йөргәнгә — пошыкма.* Мәкаль.

ПОШЫМ *и. диал.* Читләренә киндер тукыма тотып, күннән йомшак итеп тегелгән бөрмәле кага.

ПОШЫМСЫЗ *с.* Ваемсыз, гамьсез, борчылмаучан. *Җирдә ашап утырган өч коралсыз солдатның бу кадәр пошымсыз булуларын, бу кадәр тыныч карау-*

ларын ничек аңларга? Ә. Еники. *Солтан искиткеч пошымсыз, ялкау, эшлексез булып чыккан.* Г. Гали.

ПОШЫНУ *ф.* Күңел тынычсызлану, хафалану, борчылу. [*Ул*] *пошынган тавыш белән: „Дөнәй нишләп бик озак кайтмый икән?" — диде.* Ш. Камал. *Башкалар Якупның язмышы өчен пошыналар.* Ә. Айдар.

ПОШЫНУЛЫ *с.* Борчулы, хафа белдерә, чагылдыра торган. *Шакирның бөтен нервлары дулкынландылар, ул, үз-үзенә хисап та бирмәстән, әллә нинди бер --- пошынулы тавыш белән: „Сез, әсма, бераз калыгыз минем янымда..." — [диде].* Ф. Әмирхан. *Әгәр дә үзем турында бераз пошынулы сүзләр әйтеп, ризасызлык күрсәтеп ташлаганмын икән, аңарга минем сылтауларым бар.* К. Басыйров. || Борчулы, хафалы (тынлык, хәл, кеше һ. б. ш. турында). *Зәйнак һаман пошынулы һәм өметле уйларда газапланып утыруын ташлады.* Ш. Маннур. *Айсылу бу пошынулы тынлыкка уңайсызлана башла[ды].* Г. Бәширов.

ПОШЫНУСЫЗ *с. к.* пошмас.

ПОШЫНУСЫЗЛЫК *и.* Гамьсезлек, ваемсызлык, борчылмаучанлык. *Кадыйровның бу сүзләрне үтә бер салкынлык һәм гаҗәеп бер пошынусызлык белән әйтүе болай да каны кызган сержантка үткер штык белән кадагандай тәэсир итте.* Г. Әпсәләмов.

ПОШЫРГАЛАНУ *ф. сөйл.* **1.** *к.* пошыну. *Фазылҗан абзый, сызлаулы аякларын ничек тә ипләбрәк суза алмыйча, сүзсез генә пошыргаланып утыра.* Р. Төхфәтуллин. *Башка вакытта ындыр табагына барып җиткәнче рәхәт кенә черем итә торган Хәнәфи бу юлы пошыргаланып, борчылып утырды.* А. Гыйләҗев.

2. Үзендә авырлык, тышкы кысанлык сизеп, аяк-кулларын төрле якка атып, бәргәләп, тынычсыз яту, утыру.

ПОЭ'ЗИЯ *и.* **1.** Фикерне сүзләр ярдәмендә образлы чагылдыру сәнгате, (башлыча шигъри) сүз сәнгате.

2. Шигырьләр, тезмә сөйләм (әдәбиятның бер төре). *Г. Камалның әдәбият өлкәсендә драматургиядән кала иң күп эшләгән жанры — поэзия.* М. Гали. *Женя поэзияне үлеп ярата һәм бик күп шагыйрьләрнең әсәрләрен яттан белә.* Каз. утл. || *әд.* Берәр халыкның, чорның, иҗтимагый төркемнең һ. б. ш. шигъри, тезмә әсәрләр җыелмасы. *Антик поэзия. Татар поэзиясе.* □ *Демократик поэзия вәкилләре булган Г. Тукай һәм М. Гафуриның да [иҗтимагый] мәсьәләләрне куюда аермалары бар.* М. Җәлил.

3. *күч.* Хисләргә, хыялга бик нык тәэсир итә торган нәрсә, нәфислек, гүзәллек, шигърият. *Тормыш поэзиясе. Табигать поэзиясе. Хезмәт поэзиясе.* □ *— Д мин бу матурлык, поэзия дөньясыннан ничек аерылырмын?* Ә. Фәйзи. *Бу ике шигырьдә нинди лә тафәт, нинди нәфасәт, нинди поэзия!* Г. Тукай.

ПОЭ'МА *и.* **1.** Шигырь белән хикәяләп язылган зур әдәби әсәр. *Лирик поэма. Эпик поэма. Дидактик поэма.* □ *Поэмада, романдагы яки повестьтагы кебек үк, җәелеп-үсеп бара торган бердәм сюжет сызыгы булырга, әсәрнең башыннан ахырына кадәр дәвам иткән образлар булырга, эштә, хәрәкәттә ачыла торган характерлар булырга тиеш.* Г. Гобәй. *Бүгенге көнне, аның героикасын, аны иҗат итүче кешеләрнең героик образларын тудыру буенча әдәбият алдына куелган бурычларны хәл итүдә зур күләмле поэтик әсәрләрнең — поэмаларның роле бик зур.* Ә. Исхак.

2. *күч.* Тойгыларга, аңга бик нык тәэсир итә торган нәфис, гүзәл, искиткеч нәрсә. *Гади йортлар түгел, Поэмалар күтәрелә безнең урамда!* З. Мансур.

3. Ирекле формадагы, лирик яки программ характердагы музыкаль әсәр исеме. [*Остаз*] *шул кәгазьләрне рояль өстенә туздырып ташлады да, башын чайкый-чайкый, кайбер өзекләрне уйнап, анализлап, поэманы бөтенләй юкка чыгарды.* Ш. Хөсәенов.

ПОЭ'ТИК *с. к.* шигъри. *Соңгы елларда матбугатта игълан ителгән күп сандагы поэтик әсәрләрдән С. Хәкимнең „Бакчачылар" исемле поэмасы күренекле урын тота.* Г. Гобәй.

ПОЭ'ТИКА *и. әд.* **1.** Әдәбият белеменең шигъри әсәрләр төзелешен, шигъри формасын, поэтик сәнгать алымнарын, поэзияне анализлау принципларын өйрәнә торган бүлеге.

2. Берәр шагыйрьнең яки әдәби мәктәпнең поэтик чаралар һәм принциплар системасы. *Тукай поэтикасы. Романтизм поэтикасы.* □ *Д. Фәтхинең шигырь стиле, поэтикасы Такташныкыннан шактый аерыла.* Н. Юзиев, Ә. Кәримуллин.

ПОЭ'ТИКЛАШТЫРУ *ф. кит.* Матурлап, бизәп күрсәтү, шигъри төскә кертү; шигъриләштерү. *Табигать стихиясен поэтиклаштыру.*

ПО'ЯС *и.* **1.** *геогр.* Җир шарының ике меридиан арасындагы өлеше.

2. *геогр.* Җир шарының билгеле бер климат зонасы булып саналган өлеше. *Эссе пояс. Салкын пояс.* || Җир шарының үзенә хас табигый үзенчәлекләре, сыйфатлары булган бер кисәге, бүлемтеге. *Чүлләр поясы.*

3. *с. мәгъ.* Поясларга (1, 4 мәгъ.) карап исәпләнә, билгеләнә торган. *Пояс вакыты. Пояс тарифы.*

4. *экон.* Илнең экономик билгеләргә нигезләнеп бүлгәндә килеп чыккан бер өлеше, зонасы. *Тариф поясы. Илне промышленность һәм азык-төлек товарлары бәясенә карап поясларга бүлү.*

ПРА'ВДАЧЫ *и.* РСДРП(б) үзәк органының — „Правда" газетасының беренче чыккан елларында (1912—1914 еллар) большевикларның гомуми атамасы. || КПСС Үзәк Комитеты органы „Правда" газетасы хезмәткәрләренең хәзерге атамасы.

ПРАВИЛА *и. сөйл.* Агач линейка, тигезләгеч. *Хәлфә абыйлары --- бик ачуы килгән чакта, тешләрен кысып, правила белән суга яисә китап белән тондыра.* И. Гази. [*Укытучы*] *кулындагы китапның правила кыстырган җирен ачты.* Ш. Маннур.

ПРАВОСЛА'ВИЕ *и.* Көнбатыш илләрдә хакимлек иткән католиклыктан аермалы буларак, Византиядә барлыкка килгән Көнчыгыш христиан дине. *Иеромонах Ильядор --- православиедән яһүдилеккә чы[ккан].* Г. Тукай. [*Гәрәй хәлфә*] *Казандагы чиркәүләрнең берсендә тантаналы рәвештә православие диненә күчә.* М. Гали. || Патша Россиясендә рәсми дин.

ПРАГМАТИЗМ *и.* **1.** Хәзерге буржуаз философиядә: хакыйкать дип объектив чынбарлыкка туры килә торган нәрсәләрне түгел, бәлки буржуазия өчен практик яктан файдалы булган нәрсәләрне генә танучы реакцион субъектив-идеалистик агым. *Прагматизмга нигез салучы Америка философы Чарльз Пирс идеяләрнең әһәмияте аларның практик нәтиҗәләрендә дигән карашны алга сөрде.* М. Абдрахманов. [*Ленин*] *прагматизмның идеалистик, реакцион эчтәлеген фаш итте.* К. Фасеев.

2. Тарих фәнендә аерым вакыйгаларны, тарихи үсешнең объектив законнарын исәпкә алмыйча, аларның тышкы бәйләнешләрен һәм тышкы эзлеклелеген генә күздә тотып сурәтли торган юнәлеш.

ПРАГМА'ТИК I *и. к.* прагматист.

ПРАГМА'ТИК II *с.* Прагматизмга нигезләнгән. *Прагматик философия.*

ПРАГМАТИ'СТ *и.* **1.** Прагматизм (1 мәгъ.) тарафдары. *Төшенчә һәм категорияләрдә объектив эчтәлекнең булу-булмавы, аларда безнең белемнәребезнең гомумиләштерелүе прагматистларны кызыксындырмый.* М. Абдрахманов. *Д Габбаслар — зирәк! Прагматистлар фәлсәфәсе — тулы килеш алар яклы.* Ә. Баянов.

2. Тарихи фактларны прагматизм (2 мәгъ.) күзлегеннән тасвирлый торган тарихчы.

ПРАКТИК I *и.* 1. Үз белгечлеге буенча зур тәҗрибәсе булган, шул өлкәдә күп эшләп махсус белем туплаган кеше; *киресе:* теоретик. — *Сез ни өчендер практик-геолог Степан Андреевичның, нефть исен иснәп үскән буровой мастер Хәмидуллинның сүзләрен ишетергә теләмисез.* А. Әхмәт. — *Әбез практик кына булып йөрик, шунда да сер сынатмабыз әле.* Ә. Еники.

2. *күч.* Эшнең практик II (5 мәгъ.) ягын күзәтә, эшнең файдасы булуга игътибар итә торган кеше.

ПРАКТИК II *с.* 1. Практика (2 мәгъ.) белән, берәр нәрсәне тормышка ашыру белән, реаль ихтыяҗлар һәм мөмкинлекләр белән бәйле. *Практик эшчәнлек. Практик киңәш. Практик максат.* □ — *Сез тәкъдимегезне фәнни яктан ачып салмагансыз, бу бары тик практик яктан гына карап төзелгән.* Т. Гыйззәт. *Г. Камал — татар әдәби телен үстерүдә иң зур практик эш күрсәткән язучыларның берсе.* М. Гали.

2. Берәр эш белән турыдан-туры шөгыльләнә яки җитәкчелек итә торган. *Практик үзәк.* □ *Татарстан партия оешмасы һәм хөкүмәте җитәкчеләренең --- практик җитәкчелек итүләре аркасында, коллектив бу зур күләмле катлаулы эшләрне үтеп алды.* М. Җәлил.

3. Өйрәнгән белемнәрне, күнегүләрне эштә, практикада (2 мәгъ.) куллануга бәйләнешле. *Практик дәресләр.* □ *Бу бит әле биология буенча практик эш тә булачак.* Г. Гобәй. *[Кульязмада] дүрт кырлы пирамиданың күләмен исәпләү һәм башка практик мәсьәләләр бирелгән.* Ж. Тәрҗеманов. || Белемнең, фәннең берәр тармагын практикада куллану һәм кулланылган белән бәйләнгән. *Практик механика. Практик мәктәп.* □ *Практик грамматикаларда сүз төркемнәрен сораулар буенча аерту алымы бик киң кулланыла.* В. Хангилдин. *Павлов хезмәтләре практик медицинаның алга китүенә зур этәреш ясады.* Сов. әд.

4. Тормыш, эш мәсьәләләрен яхшы аңлый торган, реаль нәтиҗәләрне, реаль файда китерә торган нәрсәләрне генә кулай таба торган; эшлекле. *Практик фикер йөртү.* □ *Тумыштан килә торган практик акылы, тапкырлыгы белән [Гыймран] теләсә кайсы инженерны төп башына утырта ала.* Г. Ахунов. — *Син ташып торган тойгы кешесе идең, салкын, практик акыл сиңа чит иде.* Ә. Фәйзи.

5. Теге яки бу сыйфатлары белән файдалы, яраклы, унайлы. *Практик метод.*

ПРАКТИКА *и.* 1. *филос.* Кешеләрнең җәмгыять яшәеше өчен кирәкле шартларны тудыруга юнәлдерелгән барлык эшчәнлеге. *Теориянең практикага тәэсире.* □ *Практика дигән төшенчә эченә бер буын, бер токым, яки бер иҗтимагый-экономик формациядә җыелган, яки бер илдә булган тәҗрибә генә алынмый. Монда гасырлар буе, барлык илләр һәм халыклар тарафыннан җыйналган тәҗрибә күздә тотыла.* М. Абдрахманов.

2. Фикерләрне, нәтиҗәләрне тормышка ашыру һәм сынау җирлеге буларак тормыш, чынбарлык. *Без аның ялгышканын практикада исбат итәчәкбез.* Ш. Камал. *Нургалинең мондый хәлне практикада сынаганы бар.* Ә. Еники.

3. Белемнәрне, күнегүләрне эштә куллану. || Укуукыту процессының состав өлеше буларак, теоретик белемне тормышта куллану һәм ныгыту. *Студентларның педагогик практикасы. Производство практикасы.*

4. Эшчәнлекнең билгеле бер өлкәсендә тупланган тәҗрибә, эш алымнары һәм күнегүләр жыелмасы; эш, тәҗрибә. — *Медицина фәнендәге практиканың бөтен мөмкинлекләреннән файдаланып, аны коткарырга тырышабыз.* Ш. Камал. — *Минем 25 еллык практикам бар.* Р. Ишморат.

5. *иск.* Врач яки юрист эшчәнлеге. *Хосусый практика.*

Практикага кертү — берәр төрле эш эшли башлау; берәр эш ысулы куллана башлау. *[Редакция] журналга кушымта рәвештә әдәби җыентыклар бирү юлын практикага кертер.* М. Җәлил.

ПРАКТИКАНТ *и.* Өйрәнү, практик белемнәр алу өчен берәр учреждениегә, предприятиегә беркетелгән белгеч, эшче, укучы. — *Бүген өч операция уздырдык. Икесе хатын-кыз. Боларын практикант врачлар ясады.* Э. Касыймов. — *Безнең практикантлар — Мәскәүдә укучы Вьетнам студентлары.* М. Хөсәен.

ПРАКТИКУМ *и.* Башлыча югары уку йортларында: берәр фән буенча практик дәресләр төре. *Рус теленнән практикум үткәрү.*

ПРАКТИЦИЗМ *и. кит.* 1. Теориягә тиешенчә әһәмият бирмичә, практик эшчәнлекне өстен, артык күю.

2. Берәр нәрсәнең практик файдасын күз алдында тотып эш итүчәнлек. — *Каян килә хәзерге яшьләрдә шул чаклы практицизм?* Г. Ахунов.

ПРАКӘНДӘ *рәв. иск.* Чәчелеп, тузгып, таралып. *Пракәндә яткан кәгазьләрне бер жиргә җыйнап куярга уйладым.* М. Гафури. || *с. мәгъ.* Чәчелгән, тузгыган, таралган. *Бервакытны пракәндә кәгазьләр арасында табылган бер төрек шагыйренең бер шигыре аңа гаять тәэсир иткән икән.* Г. Кәрам.

Пракәндә итү (китерү) *иск.* — туздыру, тарату. *Революция капиталны һәм аның хуҗаларын пракәндә иткәч, алар таралалар.* М. Гафури.

ПРАКӘНДӘЛЕК *и. иск. кит.* Таркаулык, тәртипсезлек. *[Аның] күңеле тәшвишләрдән вә пракәндәлекләрдән [буш] булмас.* К. Насыйри.

ПРАН-ЗАРАН *рәв. к.* пыран-заран. *Малайлар дәррәү урыннарыннан кузгалып, берсе алга, берсе артка китеп, этешә-төртешә, пран-заран килеп беттеләр.* М. Гали. *[Назимовның] бу башмакларны пран-заран китереп төрлесен-төрле якка атып бәрәсе килә башлый иде.* Г. Әпсәләмов.

ПРАНЛАТУ *ф. к.* пыр туздыру. *[Хәллә] бик яман сүз әйтеп сүгенергә теләде. Әптелмәннекеләрне пранлатып куып чыгарырга булды.* Ф. Хөсни.

ПРАПОРЩИК *и.* 1. Патша армиясендә иң кече офицер чины, шул чиндагы кеше. *Уралның нәкъ уртасына җиткәч, прапорщик команда бирә.* Ш. Усманов. *Петроградтан бер прапорщик кайткан.* К. Нәжми. || *с. мәгъ.* Шул чиндагы офицерлар хәзерли торган. *Шәһәрдәге гаскәри гарнизонның бөтен составы диярлек — прапорщиклар мәктәбе җыемеиляре.* Ш. Камал.

2. Совет Армиясендә, диңгез авиациясендә, чик буе һәм эчке гаскәрләрдә сроктан тыш хезмәт итүче кече командир.

ПРАХЛАУ *ф. сөйл.* 1. Кабалану, атылып-бәрелү. *Тавык прахлау.*

2. *рәв. мәгъ.* **прахлап**. Кабаланып, атылып-бәрелеп. *Пич астыннан песи чыкты прахлап.* Г. Тукай.

ПРЕАМБУЛА *и. кит.* Берәр мөһим договорның, халыкара килешүнең, актның кереш өлеше. *Договор преамбуласы. Резолюция преамбуласы.*

ПРЕВЕНТИВ *с. кит.* Саклану өчен, алдан кисәтү максаты белән ясалган. *Превентив һөҗүм. Превентив прививка.*

Превентив сугыш — сугышка хәзерләнүче дошманның һөҗүменә юл куймас өчен алдарак башланган сугыш.

ПРЕДВОДИ'ТЕЛЬ *и.* (Берәр кабилә, гаскәр, төркем һ. б. ш.) белән җитәкчелек итүче, башлык. *Дворяннар предводителе.*

ПРЕДИКАТ *и.* **1.** *лог.* Фикер йөртүнең предметы турында хөкем; логик хәбәр. *Хөкемдә һәрвакытта да субъект, предикат һәм бәйләгеч була.* М. Зәкиев.

2. *лингв.* Хәбәр (5 мәгъ.).

ПРЕДИКАТИВ *с. лог., лингв.* Асылы предикат булган. *Предикатив бәйләнеш (*мәсәлән: *Мин укыйм).*

ПРЕДИКАТИВЛЫК *и. лог., лингв.* Предикатив булу; хәбәрлек. *Тел галимнәренең күпчелеге исә җөмләнең бу икенче билгесен предикативлык дигән термин белән атап йөртә.* В. Хангилдин.

ПРЕДМЕТ *и.* **1.** Сизү әгъзалары тарафыннан яшәве беленә торган теләсә нинди конкрет җисем, әйбер, күренеш. [*Борынгы заманда*] *предмет атамаларын яки анда колакка беренче булып ишетелгән телләсә нинди ят сүзне кеше балаларына исем итеп тагу модада булган.* Н. Фәттах.

2. Һәртөрле фикерләү, сөйләм, танып-белү һәм иҗади эшчәнлекнең эчтәлеген тәшкил иткән нәрсә, тема. *Фәнни-тикшеренү предметы.*

3. Уку-укыту эшендә өйрәнелә торган аерым фән. — [*Хатыным*] *зачётларын биреп бетергән. Бөтен предметлардан диярлек „отлично" алган.* Ш. Камал.

ПРЕДМЕТЛАП: предметлап укыту системасы — мәктәптә һәр аерым предметны үзенә бер укытучы укыту системасы.

ПРЕДМЕТЛЫК *и.* Предмет булу, әйберлек. *Телдә предметлык категориясе.* ▭ *Сүз төркемнәре предметлык, билге, процесс һ. б. ш. мәгънәләрне белдерү буенча аерылалар.* Д. Тумашева. *Югарыда исемнең төп семантик билгесе предметлык төшенчәсе икәнлек аңлатылды.* В. Хангилдин.

ПРЕДМЕТЛЫЛЫК *и.* Берәр нәрсәдә матди эчтәлек булу, предметлар, әйберләр дөньясы белән бәйләнеш. *Сәнгатьнең предметлылыгы.*

ПРЕДОХРАНИ'ТЕЛЬ *и.* Берәр төрле хәтәр тәэсирдән, берәр ярамас эштән саклый торган җайланма; саклагыч. *Электр предохранителе. Радиоалгыч предохранителе.* ▭ *Инженер предохранительне чыкылдатып ычкындырды, мылтыкны аучыларча җиңел генә иңенә терәде.* Г. Ахунов. *Аз гына кагылып китүгә, имән бүрәнә мина предохранителе өстенә шап итеп төшәчәк. Бу көч шартлату өчен җитә.* Ш. Рәкыйпов.

ПРЕДПАРЛА'МЕНТ *и.* 1917 елның сентябрендә Россия Вакытлы хөкүмәте Демократик киңәшмә вәкилләренең бер өлешеннән төзегән киңәш бирү хокуклы вакытлы совет. *Искәндәр — Учредительное собрание, милләт мәҗлесе, предпарламент эгъзасы.* Г. Газиз.

ПРЕДПРИНИМА'ТЕЛЬ *и.* Промышленность, сәүдә һ. б. ш. предприятиеләр хуҗасы — капиталист. *Әре предприниматель. Предпринимательләр берләшмәсе.* ▭ *Тимербулатов көнен-төнен чаба, заводларда, конструкторлык бюроларында, предпринимательләрдә була.* А. Расих.

ПРЕДПРИНИМА'ТЕЛЬЛЕК *и.* Предприниматель эшчәнлеге.

ПРЕДПРИЯ'ТИЕ *и.* Җитештерү яки сәүдә берәмлеге (мәсәлән, завод, кибет һ. б.); шундый берничә берәмлек берләшмәсе. *Вак предприятие. Дәүләт предприятиесе. Хосусый предприятие.* ▭ *Промышленность предприятиеләренең административ-хуҗалык расходларын киметү[ик].* А. Шамов. *Завод белән якынрак танышкач, бу ике предприятие арасында турыдан-туры бәйләнеш барлыгына ышандык.* Г. Ахунов.

ПРЕДСЕДА'ТЕЛЬ *и.* **1.** Җыелышны яки утырышны алып бару өчен сайланган кеше; рәис. *Җыелыш председателе кыңгыравын баш очына күтәреп каты-каты шалтыраткач кына тынды зал.* Г. Гобәй.

2. Кайбер учреждение, берләшмә, җәмгыять, оешма яки алардагы бүлекләрнең җитәкчесе. *Райбашкарма председателе. Авыл советы председателе. Комитет председателе.* ▭ *Колхозның беренче председателе итеп Гали абзыйны сайлыйлар.* Г. Әпсәләмов. — *Гаризагызны карадык, — диде комиссия председателе.* А. Шамов.

3. *(Баш хәреф белән.)* Югары дәүләт органы яки хөкүмәт, дәүләт җитәкчесенең рәсми атамасы составында кулланыла. *ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе. СССР Верховный Суды Председателе.* ▭ [*Аны*] *обком секретаре белән Верховный Совет Председателе котларга килә.* Т. Гыйззәт.

ПРЕДСЕДА'ТЕЛЬЛЕК *и.* **1.** Председатель вазифаларын башкару эше, председатель вазифасы, председатель хезмәте. *Аны тагын председательлеккә сайладылар.* Ш. Камал. — *Мине ни өчен председательлектән төшерделәр?* М. Әмир.

2. *у.-вак. килеш., тарт. форм.* **председательлегендә.** Кемнең дә булса җитәкчелегендә. *Җыелышны Сабиров председательлегендә алып бару.* ▭ *Бу мөһим мәсьәләне тикшерер өчен Жуков председательлегендә ашыгыч комиссия төзелде.* С. Баттал.

Председательлек итү — председатель вазифаларын үтәү, председатель булу. [*Лобачевский*] *кабул итү сынауларында һәрвакыт председательлек иткән.* Ж. Тәржеманов.

ПРЕЗЕРВАТИВ *и.* Балага узудан һәм венерик авыру йогудан саклану өчен кулланыла торган бик юка, кечкенә яры (полиэтилен) капчык. [*Немец әсиренең*] *кайсысының гына кесәсен актарма, тартма-тартма презервативка очрыйсыз.* Х. Мөҗәй.

ПРЕЗИДЕНТ *и.* **1.** Берәр җәмгыятькә яки учреждениегә җитәкчелек итү өчен сайланган председатель. *СССР Фәннәр академиясе президенты. „СССР—Франция" җәмгыятенең президенты.* ▭ *Пункт президентының безгә әйтүенә караганда, бу оешма биш ел эчендә ике мең кешегә хезмәт күрсәткән.* Каз. утл.

2. Билгеле бер срокка республика башлыгы итеп сайланган кеше. *Чехословакия Социалистик Республикасы президенты. АКШ президенты.* ▭ *Самодержавиенең кешеләре, президент Рузвельт булышуы аркасында, - - - японнарның бик күп теләгән нәрсәләренә разый бул[дылар].* РСДРП прокламациясе.

ПРЕЗИДЕНТЛЫК *и.* **1.** Президент вазифасы, хезмәте, урыны, исеме. *Президентлыкка сайлаулар.* ▭ [*Нью-Йорктa*] *һәр почмакта президентлыкны дәгъвалаучыларның рәсемнәре төшерелгән значоклар сатып утыралар.* Каз. утл.

2. Президент булып торган вакыт; президент эшчәнлеге.

ПРЕЗИ'ДИУМ *и.* Җыелыш яки киңәшмәне алып бару өчен сайланган орган. *Президиум члены.* ▭ *Җыелышны алып бару өчен өч кешелек президиум сайларга тәкъдим итәм.* Ш. Камал. *Президиум өстәле артында — МТС вәкиле, колхоз җитәкчеләре, производство алдынгылары.* Ә. Маликов. || Кайбер оешмаларның яки учреждениеләрнең җитәкче органы. *СССР Фәннәр академиясе президиумы. Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы.* || *җый.* Шул органга кергән кешеләр. — *Аппарат янында Төркстан Совнаркомы президиумы.* Ш. Усманов. *Якуб Совет президиумын җыйды.* И. Гази.

ПРЕЗУ'МПЦИЯ *и. махс.* Берәр фактны киресе расланганга кадәр юридик яктан дөрес дип табу. — *Гаепсезлек презумпциясен онытмагыз. Ул үзенең гаепсез икәнен исбат итәргә тиеш түгел.* М. Маликова.

ПРЕЙСКУРАНТ *и.* Товарларның төрләре һәм бәяләре турында белешмә. [*Официант:*] *Рәхим итегез, нәрсә китерик? Менә прейскурант. Рәхим итеп шуннан карап әйтегез.* Г. Камал. *Ни телисез? Пожалуйста, мәгез прейскурант! Коньяк, дисез; була!* Ф. Кәрим.

ПРЕЛАТ *и.* Католик һәм англикан чиркәүләрендә югары дәрәҗәле рухани (архиепископ, епископ, монастырь башлыгы). *Австриянең өстен палатасы --- принцлардан, --- прелатлардан тора.* Г. Коләхметов.

ПРЕЛЮ'ДИЯ *и. муз.* 1. Музыкаль әсәргә кереш.

2. *күч.* Берәр нәрсәнең башлангычы, кереше. *Европада фашизмның дәһшәтле карачкысы [күтәрелүен] --- без әле шул көтелгән сугышның прелюдиясе [икәнен] һәм ил өстенә шундый афәт булып ябырылачагын һич тә ул кадәр күз алдына китерә алмый идек.* Г. Бәширов.

3. Ныклы формасы булмаган һәм күбесенчә фортепьяно өчен язылган мөстәкыйль музыкаль пьеса. *Хәбир Шопенның атаклы циклыннан бер прелюдия уйнады.* Ш. Хөсәенов. [*Надя*] *классик музыкадан этюдлар, прелюдияләр уйнады.* Р. Төхфәтуллин.

ПРЕМИАЛЬ *с.* Премия итеп бирелгән, премия бирү өчен билгеләнгән. *Премиаль хезмәт хакы. Премиаль фонд.*

ПРЕ'МИЯ *и.* 1. Билгеле бер өлкәдә ирешкән уңышлары, күрсәткән хезмәтләре өчен бирелә торган бүләк. *Халыкара тынычлык премияләре. Ленин премияләре.* □ *Михаил Шолоховка халыкара бүләк — Нобель премиясе бирелде.* Ф. Хөсни.

2. Производство нормасын яхшы сыйфат белән арттырып үтәгән өчен эшче һәм хезмәткәрләргә хезмәт хакыннан тыш бирелә торган өстәмә түләү. *—Мин кичә квартал --- планын арттырып тутыруыбыз өчен биш мең сум премия алдым.* Т. Гыйззәт. *— Яхшы эшләгәне өчен малайга премия дә бирәләр.* Ш. Камал.

ПРЕМЬЕР *и.* 1. *к.* премьер-министр. *Премьер өйдә юк иде.* М. Мәхмүтов.

2. *театр.* Баш рольләрне башкаручы артист. *Труппа премьеры.*

ПРЕМЬЕ'РА *и.* Пьеса, опера, балет һ. б. ш. ларның беренче мәртәбә сәхнәгә куелышы. *Фатих Әмирханны декабрь аенда „Сания" операсы премьерасында күрдем. Татарның культура тарихында опера сәнгате туган көн иде бу.* Э. Еники. *Сыртлановның бу балеты --- моннан берничә ел элек куелып, премьерасында ук җылы кабул ителгән иде.* Ш. Хөсәенов.

ПРЕМЬЕРЛЫК *и.* Премьер вазифасы, премьер хезмәте.

ПРЕМЬЕ'Р-МИНИ'СТР *и.* Хөкүмәт башлыгы, министрлар советы председателе яки министрлар кабинеты председателе. *Һиндстан премьер-министры.*

ПРЕПАРАТ *и.* 1. Хайван яки үсемлек организмының тикшеренү, өйрәнү өчен хәзерләнгән кисәкләре. *Анатомия препараты. Бака йөрәге препараты.* □ *Препаратлар ясауга гаять оста булып өйрәнеп җиткәнлеге өчен, ул медицина факультеты студентларының укулары вакытында аларга якын ярдәмче булды.* И. Рәмиев.

2. Тикшеренү өчен хәзерләнгән химик матдә. *Радиоактив препарат.*

3. Фабрикада, лабораториядә хәзерләнгән химик продукт яки дару. *Йодлы препарат.* □ *Паратиф авыруына каршы яңа препарат кайткан.* Г. Насрый. *Бу препаратны сиптереп берничә сәгать үтүгә, чүп үләннәре саргаеп, шиңеп төшәләр.* Г. Галиев.

ПРЕПАРА'ТОР *и.* Фәнни учреждениеләрдә препаратлар хәзерләүче хезмәткәр. *— Сезнең кул астында, әгәр шулай әйтергә мөмкин булса, бары ике генә кеше — препаратор Настенька һәм этләр караучы кала.* А. Расих.

ПРЕПАРА'ТОРЛЫК *и.* Препаратор хезмәте, препаратор вазифасы.

ПРЕПОЗИТИВ *с. лингв.* Берәр сүз яки сүз тезмәсе алдында торган. *Препозитив кисәкчә* (мәсәлән, ***иң*** *яхшы).* □ *Кисәкчәләр сүзнең алдында (препозитив позициядә) һәм азагында (постпозитив позициядә) куелалар.* Д. Тумашева.

ПРЕПОЗИ'ЦИЯ *и. лингв.* Берәр җөмлә кисәгенең үзе турыдан-туры буйсынган яки ярашкан җөмлә кисәге алдында торуы (мәсәлән: ***кызыл*** *байрак*).

ПРЕ'РИЯ *и.* Төньяк Америкада уртача климат зонасындагы киң дала.

ПРЕСВИ'ТЕР *и.* Бөек Британиядә һәм кайбер башка илләрдә протестантлар оешмасының сайлап куелган җитәкчесе. *Пресвитерның чыгышы фәһгә каршы юнәлдерелгән иде.* Соц. Тат.

ПРЕСС *и.* 1. Һәртөрле әйберләрне кысып тыгызлый, эшкәртә яки ясый торган машина, җайланма; эскәнҗә. *Кул прессы. Гидравлик пресс. Печән прессы.* □ *Әле күптән түгел генә [завод] насослар һәм прессларэшләп чыгарган.* Г. Әпсәләмов.

2. *сөйл. к.* пресс-папье (2 мәгъ.). *Кәгазьләр очмасын өчен, директор аларны мәрмәр пресс белән бастырып куйды.* М. Маликова.

ПРЕ'ССА *и.* Вакытлы матбугатның (газета-журнал һ. б. ш. ның) гомуми исеме. *Буржуаз пресса.* □ *—Ул инде журналист булган да иде. --- әлбәттә, сул прессада.* Э. Касыймов. || *җый.* Вакытлы матбугат вәкилләре; журналистлар. *Стадионда пресса өчен урыннар.*

ПРЕСС-АТТАШЕ *и.* Дипломатик вәкиллекнең (илчелекнең, миссиянең һ. б. ш. ларның) матбугат мәсьәләләре белән шөгыльләнүче хезмәткәре. *АКШ илчелегенең пресс-атташесы.*

ПРЕСС-БЮРО *и.* 1. Һәртөрле съездлар, конференцияләр, киңәшмәләр вакытында матбугат органнарына хәбәрләр биреп тору өчен оештырыла торган редакцион аппарат. *СССР—АКШ сөйләшүләре вакытында пресс-бюро эшләү.*

2. Матбугат органнарын әзер мәкаләләр, информацияләр, иллюстрацияләр һ. б. ш. материаллар белән тәэмин итеп тору өчен матбугат, телеграф агентлыкларында һ. б. оешмаларда оештырылган даими бүлек (редакция).

ПРЕСС-КОНФЕРЕ'НЦИЯ *и.* Һәртөрле политик, фәнни һ. б. ш. мәсьәләләр буенча информация бирү өчен дәүләт, фән, җәмәгать эшлеклеләренең матбугат вәкилләре белән очрашуы. *Небенцаль Берлинда пресс-конференция уздырды.* Г. Кашшаф.

ПРЕ'ССИНГ *и.* Спорт уеннарында көндәшеңә ирекле хәрәкәт итәргә ирек бирмәү, бергә-бер уйнау (саклауның бер төре). *Футболда прессинг куллану.* □ *Казанда без прессинг (бергә-бер уйнау) кулланган идек.* Соц. Тат.

ПРЕСС-КЛУБ *и.* Журналистлар клубы.

ПРЕССЛАУ *ф.* 1. Пресс белән кысу, бастыру, тыгызлау. *Торфны прессларга.* □ *Азык-төлек вагоннарына инде прессланган* (т ө ш. ю н.) *печән тюклары төйиләр.* Г. Ахунов. *— Сездән прессларга салам алып китә [без].* М. Хәбибуллин.

2. *с. мәгъ.* Шундый эшне башкару өчен хезмәт итә торган. *Прессларга өстәле. Прессларга цехы. Прессларга аппараты.*

ПРЕСС-ПАПЬЕ *и.* 1. Астына киптергеч кәгазь беркетелгән дуга сыман пластинка яки такта (язу әсбабы). *Өстәл өстендә Толстой тоткан әйберләр: гади генә кара савыты, пресс-папье.* Э. Еники. *Сөйләшкән чакта мөдир --- өстәлдәге пресс-папьесын боргалый башлый.* А. Тимергалин.

2. Өстәл өстендә яткан кәгазьләрне бастырып куя өчен бронзадан, мәрмәрдән һ. б. ш. ясалган авыр әйбер. *Микъдат үзен үзе белмичә пресс-папье белән бик нык өстәлгә суга.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ПРЕСС-ҮЗӘК *и.* Съездларда, җыелыш-киңәшмәләрдә журналистларны, радио һәм телевидение комментаторларын тиешле информация белән тәэмин итүче матбугат органы һәм шул орган урнашкан бина; берәр әһәмиятле урында тора торган журналистлар үзәге. *КамАЗ төзелешенең үз пресс-үзәге бар. Читтән килгән журналистлар иң элек шунда керәләр.* Каз. утл.

ПРЕ'СТО *муз.* **1.** *рәв.* Бик тиз (музыка әсәрен башкару темпы турында).

2. *и.* Бик тиз уйнала торган музыка әсәре яки шуның бер кисәге.

ПРЕТЕНДЕНТ *и.* Үзенә берәр нәрсә дәгъва итүче, берәр нәрсәгә ия булырга хакы булган кеше; дәгъвачы. [*Яшь кеше*] *карт мөҗәвир урынына претендент булган.* Г. Рәхим.

ПРЕТЕ'НЗИЯ *и.* **1.** *к.* дәгъва. — *Аларның монда яшәгән квартирасына претензиям юк.* С. Баттал. — *Сез минем квартирама ниндидер претензияләр, дәгъвалар белән килдегезме?* А. Расих.

2. Берәр нәрсәгә ризасызлык, канәгатьсезлек белдерү, жалоба. — *Без бу эшне үзара килешеп эшлибез. Соңыннан безгә претензия белән килүче булмаячак.* Ә. Еники. || Урынлы таләп. — *Трестка нинди претензияләрегез бар? Нәрсә белән ярдәм итик?* Г. Ахунов.

3. *махс. кит.* Сатып алучының, кредиторның, заказ бирүченең килешү яки договор шартларын бозган подрядчыга, бурыч алучыга, заказ алучыга рәсми протест белдерүе.

ПРЕТЕ'НЗИЯЛЕ *с. кит.* Күренеклелеккә, оригинальлеккә дәгъва итүче, һавалы.

ПРЕТЕ'НЗИЯЛЕЛЕК *и.* **1.** Дәгъвачылык; дәгъва итүчелек.

2. *кит.* Кыланчыклык, һавалылык. *Күтәренке рухта язылган әсәрләрдә каһарманнарның исеменә махсус әдәбилек, пафос, шигъри мәгънә белән өртелгәнлек һәм кайчакта беркадәр претензиялелек хас булучан.* Ф. Фасеев.

ПРЕ'ТОР *и.* Борынгы Римда: башта консул һәм диктатор титулы, соңыннан — иң югары суд власте башлыгы.

ПРЕФЕКТ *и.* **1.** Борынгы Римда: административ һәм хәрби хезмәт урыннарының һәм шул урыннарда эшләүчеләрнең гомуми исеме.

2. Франциядә департамент башлыгы. *Префект сезнең өчен пошына.* Ә. Давыдов.

3. Кайбер буржуаз илләрдә полиция начальнигы.

ПРЕФЕКТУ'РА *и.* **1.** Рим империясендә административ бүленеш берәмлеге.

2. Кайбер капиталистик илләрдә административ-территориаль берәмлек белән җитәкчелек итү органы. — *Мин префектурадан килдем сезгә.* Ә. Давыдов.

3. Префект (2—3 мәгъ.) һәм аның канцеляриясе урнашкан бина.

ПРЕФЕРАНС *и.* Карта уенының бер төре. *Залга кереп, зур сумадан преферанс уйнап, кесәңдәге бар акчаңны оттырып бетерергә генә мөмкин.* Ф. Әмирхан.

ПРЕФЕРА'НСЧЫ *и.* Преферанс уйнаучы яки шул уенны яратучы кеше.

ПРЕ'ФИКС *и. лингв.* Сүзнең алдына ялгана торган кушымча; алкушымча (мәсәлән: *„антифашист“, „амораль“* сүзләрендәге *анти-, а-* префикслары).

ПРЕФИКСАЛЬ *с. лингв.* Префикслар кушудан гыйбарәт. *Сүз ясалуның префиксаль ысулы.*

ПРЕФИКСА'ЦИЯ *и. лингв.* Префикс кушып сүз ясау ысулы (мәсәлән: ***авиа*** + *почта,* ***авиа*** + *носец* һ. б.).

ПРЕЦЕДЕНТ *и.* **1.** *кит.* Элек булган һәм шуңа охшашлы башка хәлләр өчен үрнәк яки аклану дәлиле булып хезмәт итә торган хәл.

2. *махс.* Бертөрле яки охшаш мәсьәләләрне хәл итү өчен алдан ук үрнәк итеп чыгарылган суд карары.

ПРЕЦИПИТАТ *и.* **1.** *хим.* Утырма.

2. Ак порошок сыман фосфорлы ясалма ашлама.

ПРИБОР *и.* **1.** Берәр нәрсәне үлчәү яки күзәтү, берәр нәрсә белән идарә итү һ. б. ш. максатлар өчен махсус җайланма. *Оптик прибор. Җылыту приборы. Үлчәү приборы. Приборлар төзелеше министрлыгы.* □ — *Тарасов белән газогенератор янына киләбез. Басымын күрсәткән приборларга карыйм.* Р. Ишморат. *Сәлах бу приборның (микроскопның) бик үк арзан тормаганлыгын чамалап белә.* Г. Галиев.

2. Берәр эш өчен әсбаплар җыелмасы, комплекты; җиһаз, дирбия. *Язу приборы.* □ *Укырга китәр алдыннан мин аңа кырыну приборы бүләк иттем.* Э. Касыймов. — *Кунаклар, утырышыгыз. --- Рауза, тагын өч кешелек прибор әзерләп куй.* Ә. Фәйзи.

ПРИБОРЧЫ *и.* Приборлар (1 мәгъ.) буенча белгеч, приборлар (1 мәгъ.) ясаучы. *Авиатехникларга ярдәмгә очучылар, штурманнар, приборчылар килә.* С. Баттал.

ПРИВАТ-ДОЦЕНТ *и.* Патша Россиясендә һәм Көнбатыш Европа илләрендә: югары уку йортында штаттан тыш эшләүче укытучының гыйльми исеме; шул дәрәҗәгә ия булган кеше. *Сара ханым Әхмәрова --- Бестужев исемендәге курс[та] --- приват-доцент дәрәҗәсе белән укытучы итеп калдырыла.* И. Рәмиев.

ПРИВАТ-ДОЦЕНТУ'РА *и.* Приват-доцент исеме яки хезмәт урыны.

ПРИВИ'ВКА *и. мед.* Нинди дә булса авырудан саклап калу өчен организмга кертелә торган дару. *Кызамыкка каршы прививка ясау.*

ПРИВИЛЕ'ГИЯ *и.* Өстенлек, махсус хокук. *Сыйнфый привилегияләр. Укырга керүдә привилегия бирү.*

ПРИВИЛЕ'ГИЯЛЕ *с.* Өстен хокуклы, өстен. *Привилегияле шартлар. Привилегияле катлам кешеләре.*

ПРИВОД *и. тех.* **1.** Нинди дә булса машинаны, механизмны һ. б. ш. хәрәкәткә китерү өчен җайланма. *Электрик привод. Атлы привод.*

2. Әйләнү хәрәкәтен электр чыганагыннан, двигательдән машиналарга, станокларга күчерү җайланмасы. *Каеш привод.* □ *Кар астындагы ат приводын алыр өчен берничә кеше тимер көрәкләр белән будка янындагы кар өемнәрен актаралар.* Ш. Камал.

ПРИГОВО'Р *и. сөйл.* **1.** Суд карары, суд хөкеме.

2. Берәр оешма, коллектив яки җыелыш карары. — *Дти мине порукага алырга килсә дә, штаб бирми, авылыгыз приговор ясап сорасын, ди икән.* Н. Исәнбәт. [*Байлар*] *тиз генә приговор ясап,* [*Җиһанша*] *биек мәчеткә имам булып мәхәлләгә күчте.* З. Һади.

ПРИЗ I *и.* Ярышта өстен чыгучыга бирелә торган бүләк. *Призлар Шамил катнашында яулап алынды.* Р. Ишморатова.

ПРИЗ II *и. махс.* Диңгез сугышы вакытында яулап алынган һәм халыкара хокук буенча яулап алучының милкенә әверелә торган дошман судносы яки башка төрле мал-мөлкәт.

ПРИЗЁР *и.* Приз I алучы кеше. *Советлар Союзы чемпионаты призёры Наташа Киселёва (Волгоград) бу ярышта да югары нәтиҗәләр күрсәтте.* Соц. Тат.

ПРИЗЛЫ *с.* Ярышларда приз I бирелә торган. *Су спорты ярышларында катнашып,* [*Гыйльманов*] *Татарстан күләмендә призлы урыннарның берсен яулап алган.* Ф. Хөсни. *Кайбер талантлы яшьләребез*

Бөтенсоюз шигырь фестивальләрендә призлы урыннар ал[ды]. Р. Фәйзуллин.

ПРИ'ЗМА *и.* **1.** *мат.* Ике нигезе бер-беренә параллель тигез күппочмаклардан һәм ян кырлары параллелограммнардан гыйбарәт күпкырлы җисем. *Туры призма.*

2. *физ.* Үтә күренмәле материалдан ясалган һәм катлаулы яктылыкны спектрга таркату, яктылык нурларының юнәлешен үзгәртү һ. б. максатлар өчен оптик, спектраль приборларда, аппаратларда кулланыла торган күппочмаклык яки өчпочмаклык. *Түгәрәк трубадай өскә сузылып призма үсә башлый. 30 см озынлыкта булгач, формага кертеп кисеп алалар.* Р. Бәһау.

3. *күч. чыг. килеш форм.* **призмадан.** *к.* призма(сы) аша. *Ник тормышны өйрәнә белмибез, Төрле призмадан күзәтеп?* Ә. Фәйзи.

◇ **Призма(сы) аша** — берәр нәрсәгә бәйләнештә, мөнәсәбәттә, берәр нәрсә тәэсире астында, объектив булмыйча (күзәтү, карау, үткәрү һ. б. ш. турында). *Күргәннәреңне, кичергәннәреңне яңа поэтик фикерләү аша үткәр, бүгенге көн призмасы аша чагылдыр.* Ә. Давыдов. *Тормыш күренешләре әсәрдә язучының аң призмасы аша үткәннәр.* А. Гыйләҗев.

ПРИ'ЗМАЛЫ *с.* Призма куелган. *Призмалы бинокль.*

ПРИЗМА'ТИК *с.* **1.** *мат., физ.* Призма рәвешендәге. *Призматик кристалл. Призматик өслек.*

2. *физ.* Призма барлыкка китергән. *Призматик спектр.*

ПРИЗЫВ *и.* **1.** Хәрби хезмәткә алу кампаниясе. *Язгы призыв. Көзге призыв.* || *с. мәгъ.* Хәрби хезмәткә алу белән бәйле. *Призыв пункты. Призыв комиссиясе.*

2. Хәрби хезмәткә бер үк вакытта алына торган яшьтәш кешеләр. *Язгы призывны Ерак Көнчыгышка җибәрү.*

ПРИЗЫВНИК *и.* Хәрби хезмәткә алынучы кеше.

ПРИ'ИСК, ПРИ'ИСКА *и.* Кыйммәтле казылмалар, ташлар, металлар табыла торган урын. *Алмаз прискасы.* ▭ *Мин ике ел буе прискада Алтын эзләп, бөкрем чыгардым.* Ш. Маннур. *Мин яңадан бер алтын прискасына килеп ялландым.* Г. Ибраһимов.

ПРИКАЗ *и.* **1.** Оешма, учреждение, предприятие, власть органы башлыгының рәсми боерыгы. *Приказлар дәфтәре. Приказ бирү. Приказдан күчермә.* ▭ *—Монда Мирзахан гаепле түгел, прокурор приказ биргәч, үтәмичә аның хәле юк.* Т. Гыйззәт. *— Сез, Гомәрев, Фёдоров, шуларны хәзер җибәрергә кушып приказ биргез.* Ф. Сәйфи-Казанлы. || *хәрби.* Гаскәри башлык тарафыннан бирелеп, ул башлыкка буйсынган кешеләр берсүзсез үти торган әмер. *Хәрби приказ. Полк буенча приказ.* ▭ *Командир биргән приказны тулысынча үтәргә тырышам.* Ә. Айдар. *Шул вакытта атакага әзерләнергә приказ булды.* М. Гали. || Шундый әмер, боерык язылган кәгазь. *Фрунзе приказын илтү өчен тагын берничә ординарец күрше авылларга һәм дивизияләргә чыгып чапты.* Г. Бәширов.

2. *тар.* XVI—XVIII гасырларда рус дәүләтендә идарә эшләренең аерым тармагын алып барган учреждение. *Приказ палатасы. Приказ идарәсе.*

ПРИКА'ЗЧИК *и. иск.* **1.** Кибет хуҗасына ялланып, товарлар сатучы хезмәткәр. [*Байлар*] *үзләренең приказчиклары эченнән мал таный торганрагын үзләре белән Мәкәрҗәгә яки Мәскәүгә алып баралар.* Ш. Мөхәммәдев. — [*Сине*], *Гыйлаҗ байдан чыгартып, үз кибетемә приказчик итеп алырмын.* Т. Гыйззәт.

2. Алпавыт утары белән идарә итүче хезмәткәр.

ПРИКА'ЗЧИКЛЫК *и.* Приказчик булу, приказчик хезмәте. *— Миңа тырышып хезмәт итсәң, үзеңне кайткач малайлыктан приказчиклыкка күчерермен.* А. Расих. *Сафин аңа үзенең танышларыннан берәүнең галантерея магазинында приказчиклыкка урын барлыкны әйткән.* Ш. Камал.

ПРИЛА'ВКА *и.* Кибеттә сатучы белән сатып алучыларны аеру һәм товарларны күрсәтү, сату өчен алды ябык махсус озын өстәл. *Ягымлы сүз әйтә белмисең син, Прилавкага товар салганда.* З. Мансур. *Сатучы кыз --- прилавканың икенче ягына барып басты.* Р. Ишморатова.

ПРИ'МА *и. муз.* **1.** Гамманың беренче баскычы.

2. Авазлар рәтенең бер баскычындагы интервал.

3. Инструменталь ансамбльнең бер уен коралында гына алып барыла торган беренче, төп партия. || Ансамбльдә төп партияне башкаручы кеше яки ансамбльдә беренче, төп партия алып барыла торган музыка коралы.

4. Рус халык оркестрында балалайканың сопрано төре.

ПРИ'МА-БАЛЕРИ'НА *и.* Балетта төп партияләрне башкаручы биюче (балерина).

ПРИМАДО'ННА *и. театр.* Опера яки опереттада төп партияләрне башкаручы җырчы хатын-кыз.

ПРИМАТЛАР *и. күпл. зоол.* Югары төзелешле имезүчеләр төркеме (ярым маймыллар, маймыллар һәм борынгы кешеләр). *Приматлар дигән хайваннар тармагыннан беренче буларак өченчел чор маймыллары барлыкка килгән.* А. Фаткуллин.

ПРИМИТИВ *с.* **1.** Кешелек җәмгыятенең иң башлангыч стадиясендә булган; борынгы; садә, түбән төзелешле.

2. Катлаулы булмаган, гади. *Примитив техника. Примитив механизм.* ▭ *Алар кулында борынгы бабаларыбыз кулланган примитив кәйләләрне, ломнарны күрү сәер иде.* Г. Ахунов. [*Алар*] *җирне үтә примитив алымнар белән эшкәртәләр, машиналар бөтенләй кулланылмый.* Каз. утл. || Өстән-өстән генә, сай, гадиләштерелгән. *Иҗтимагый күренешләргә примитив караш.* || *рәв. мәгъ.* Сай, гадиләштереп. *Әдәбиятны болай примитив, гадиләштереп аңлау, аны асыл, тирән сыйфатларыннан мәхрүм итү кайдан килә соң?* А. Гыйләҗев.

3. Белеме һәм культурасы түбән, тар карашлы; тупас. *Бу җәвапларның һәм төпкә куелган имзаларның никадәр тупас һәм примитив ялган икәнлеге бер дә көрәшче булмаган кешегә дә күренеп тора иде.* Ш. Маннур.

ПРИМИТИВЛАШУ *ф.* Гадиләшү, тупаслану. [*Маймыл*]*ларның нәселләре ераккга киткән саен, түбәннән түбәнгә төшә барып, примитивлаша барып, суда яшәүче арка сөяксез мәхлукларга барып тоташа.* Г. Гобәй.

ПРИМИТИВЛЫК *и.* **1.** Катлаулы мәсьәләләргә чиктән тыш гади, өстән-өстән генә караш. *Аның хикәяләү стиле ндәге примитивлык, натурализмга якын сурәтләүләр язучының беренче тәҗрибәсе икәнлеген әйтеп тора.* Г. Халит. *Сәләтле шагыйрьләр арасында гадилекне еш кына примитивлыкка --- алыштыра торган иптәшләр дә җитәрлек әле.* Соц. Тат.

2. *сәнг.* XIX—XX гасыр буржуаз сәнгатенең төшенкелек белән сугарылган күп агымнарына хас булганча, примитивка иярү, аңлы рәвештә гадиләштерү.

ПРИМО'ЧКА *и.* Чүпрәккә, мамыкка сеңдереп, авырткан җиргә куела торган сыек дару. — [*Аягына*] *җылы примочка япсаң, иртәгә үк сикереп тора ул!* Ә. Фәйзи.

Примочка ясау — мамык, марля яки чүпрәкне суга яисә сыек даруга манчып, авырткан җиргә ябу.

ПРИ'МУЛА *и. бот. к.* нәүрүз.

ПРИ'МУС *и.* Керосинны насос белән горелкага өрдереп яндыра торган җылыту, кайнар ашлар хәзерләү

приборы. — *Әтисе, дим, примусны гына рәтләп бир әле. Нигәдер бик әкрен яна.* Г. Насрый. *Мөхәммәтша абзый шул примуста искиткеч тизлек белән чәйне кайнатып [та куйды].* К. Нәҗми.

ПРИНЦ *и.* Көнбатыш Европа һ. б. кайбер капиталистик илләрдә король яки князь семьясы членының титулы; шул титулдагы кеше. *Бөек шагыйрь --- югары титулларны, патша, король, принц кебек яңгыравыклы исемнәрне вакытлы нәрсәләр итеп карый.* Ш. Мөдәррис. *Императрица Мария --- Дармштатның принц кызы [була].* К. Насыйри.

ПРИНЦЕ'ССА *и.* Принц хатыны яки кызы. — *Син бит өс-башың белән, акыл-холкың белән принцесса булырлык кыз!* Ә. Фәйзи.

ПРИ'НЦИП *и.* 1. Берәр теория, тәгълимат, фән һ. б. ш. ның төп, нигез кагыйдәсе, тезисы. *Сәгатьнең гомуми принциплары, Механика принциплары.* || Берәр төр эшчәнлек өчен җитәкче кагыйдә, күрсәтмә. *Әдәбиятта партиялелек принцибы. Иреклелек принцибы. Эш принциплары. Тарихилык принцибы.* □ *Коммунист кешенең намусы чиста, вөҗданы саф булырга тиеш дигән нәрсәне син принцип итеп куйган идең.* Э. Касыймов. — *Без принцип кешеләре, — диде Фәтхи, — большевиклар үзләренә бирелгән дошманны хөкемсез дөмектермиләр.* Ш. Камал.

2. Берәр нәрсә турында төп фикер, төп караш, эчке ышаныч. *МТС җитәкчеләре бу юлы „колхозда атлар барыбер тик ята, атларга да өлеш калсын" дигән принциптан чыгып эш иткәннәр.* Ә. Маликов. *Аның үзен тиешле югарылыкта тоту принцибы бар.* А. Шамов.

3. *у.-вак. килеш., рәв. мәгъ. күч.* **принципта.** Нигездә, асылда. *Алар алпавыт малын конфискацияләүгә принципта һич тә каршы түгел.* И. Гази.

ПРИНЦИПИАЛЬ *с.* 1. Принциплар (1 мәгъ.) белән бәйле, принципларга нигезләнгән, предметның, күренешнең асылы белән бәйле. *Принципиаль каршылыклар. Принципиаль әһәмияткә ия булу.* □ — *Безнең разведкада туган принципиаль бәхәс скважина салусалмауга кайтып кала.* А. Әхмәт. || Берәр нәрсәнең асылына, нигезенә кагыла торган, әһәмиятле, мөһим. — *Мондагы кешеләр вак кына мәсьәләләргә дә принципиаль төс бирергә торалар.* Ә. Фәйзи. — *Ул бик кечкенә мәсьәлә, ипташлар! --- Принципиаль мәсьәлә түгел.* Ш. Камал. || *рәв. мәгъ.* Нигездән, тамырыннан, асылыннан. *Драматик көрәшнең идея эчтәлеге белән [әсәр] тегеләрдән принципиаль аерыла.* Г. Нигъмәти.

2. Билгеле бер принципларга гына таянып эш итә, шул принциплардан читкә тайпылмый торган. *Принципиаль политика. Принципиаль кеше.* □ *Безнең һәрберебез --- идеология өлкәсендә принципиаль, килешмәүчән булырга тиеш.* Г. Әпсәләмов. || *рәв. мәгъ.* Билгеле бер принципларга таянып, билгеле бер принциплардан читкә тайпылмыйча. *Мәсьәләне принципиаль хәл итү.*

ПРИНЦИПИАЛЬЛЕК *и.* Билгеле бер принципларны теориядә һәм тормышта әзлекле рәвештә үткәрү; принципиаль булу. — *Турысын әйтим, принципиальлегебез җитмәде. Без нәрсә әйтсәк тә, трест гел каршы килеп торды.* Г. Ахунов. — *Принципиальлек, каты куллылык — иң мактаулы сыйфатыбыз ул безнең.* Р. Ишморат.

ПРИ'НЦИПСЫЗ *с.* Билгеле бер принциплары, тотрыклы карашлары булмаган; әхлак нормалары белән исәпләшми торган. *Принципсыз кеше әзлекле хәрәкәт итә алмый.* Н. Исәнбәт. *Алар ифрат принципсыз һәм башсызлар.* Ш. Мөдәррис.

ПРИ'НЦИПСЫЗЛЫК *и.* Нык принциплар, карашлар булмау.

ПРИОРИТЕТ *и.* Фәнни ачыш ясауда, тикшеренүдә, уйлап табуда беренчелек. *Ул Гаусс аның фәнни приоритетын — яңа геометрияне иҗат итүдәге беренчелеген үзләштерергә тели дип [уйлаган].* Ж. Тәрҗеманов. *Бу яңалыкны әле миңа кадәр беркем дә ачмаган, приоритет минеке!* Н. Фәттах.

ПРИ-ПАРӘ: при-парә китерү *диал.* — пыран-заран китерү, туздыру.

ПРИПАС *и. сөйл.* Туплардан, мылтыклардан һ. б. ш. ату өчен снаряд, патрон. *Бу ике сәгать эчендә немецларның сугыш припаслары төягән берничә машинасы сафтан чыгарыла.* М. Әмир. *Авылда кызылларның 60 олау патроннары һәм башка припаслары калган.* Каз. утл.

ПРИ'СТАВ *и.* Патша Россиясендә җирле полиция башлыгы. *Пристав үзе өч полицейский белән килә дә Вахитовны богаулап ала.* Г. Ибраһимов.

ПРИ'СТАНЬ *и.* Пароходлар туктау, йөк бушату яки төяү, пассажирлар төшерү яки утырту өчен махсус җиһазланган урын, корылма. *Пристаньны да юан чылбыр белән ярга арканлап куйганнар.* И. Гази. *Пароход Казан пристаненнан яңа гына кузгалып киткән.* Р. Ишморат.

ПРИСЯ'ЖНЫЙ *и.* Буржуаз судта: суд эшләрен тикшерүгә катнаштырыла торган кеше. *Залга бер-бер артлы присяжныйлар керә башлады.* М. Галәү. *Присяжныйлар бездә маллы сыйныфлардан гына куелалар.* Урал.

Присяжный поверенный — патша Россиясе судында адвокат, яклаучы. *Хәбибулла Җиһанша углы Хәлфин — присяжный поверенный.* Х. Ямашев. *Казаннан присяжный поверенный А. Г. Бать килә.* М. Мәһдиев. **Присяжныйлар суды** — присяжныйлар катнашында уза торган суд. *Һәрбер кеше һәрбер чиновникны присяжныйлар суды алдына чакырырга хаклы.* РСДРП прокламациясе.

ПРИТОН *и.* Әшәке, бозык эшләр өчен җыела торган урын, йорт. *Караклар притоны. Сукбайлар притоны.* □ *[Сингапурда] бу урамнар артында яшерен притоннар китә. Анда әфиун тарталар, --- акчалы уеннар уйныйлар.* Р. Мостафин. *Пәрдә ачылганда жуликлар --- үзләренең притоннарында Горькийның „Кояш чыга да, бата да" җырын җырлап тор[алар].* М. Гали.

ПРИЦЕЛ *и. сөйл. к.* төзәгеч. *Батарея әзер, прицел шул ук, Бир команда, ипташ лейтенант!* М. Җәлил.

Прицелга алу *сөйл.* — мылтыкны, тупны һ. б. ш. ны берәр предметка турылап төзәү. — *Әле [төшкән] снарядлар безнең позицияләрне якты чакта прицелга алу [өчен] булган.* И. Гази. *Гаптерәхим агай көн саен таң алдыннан фермага килеп дүрт аяклы „кошчы"ны прицелга ала торган булды.* Г. Галиев.

ПРИЦЕП *и.* Автомобиль, трактор һ. б. ш. транспорт чаралары артына тагылган арба. *[Автомобильгә] махсус прицеп тагылган.* М. Хәсәнов.

ПРИЦЕ'ПЩИК *и.* Тракторга тагылган сабанда, чәчкечтә һ. б. ш. машиналарда эшләүче кеше. *Гөлсем прицепщик булу өчен Илгизәрне яшьсенде.* Г. Бәширов. — *Прицепщигымны яңа фильтр алырга җибәргән идем.* А. Тимергалин.

ПРИЦЕ'ПЩИКЛЫК *и.* Прицепщик булу, прицепщик хезмәте. *Студентларның кайберәүләре --- прицепщиклыкта йөрделәр.* Н. Фәттах.

ПРИЧАЛ *и.* 1. Пристаньның пароходлар туктау, йөк төяү һәм бушату өчен җайланмалары булган өлеше. *Йөк причалы.* □ *Казан хәзер — биш диңгез порты, аның причалларына диңгез пароходлары килеп туктый.* Г. Ахунов. *Причаллар буйлап зур порт кранналары тезелгән.* Р. Мостафин.

2. Пароход, көймә һ. б. ны пристаньга бәйләп куя торган юан аркан.

ПРИЧЁСКА *и.* Баштагы чәчләрнең тараганнан, бөдрәләткеннән, кискеннән соң булган торышы. *Причёска бозылу.* □ *Хәят причёскасын ясап бетер[де].* Ф. Әмирхан. *Зөбәйдә, чәчләрен күперткәләп: „Ошыймы сиңа минем причёска?" — диде.* Ш. Хөсәенов.

ПРИШАН *с. диал.* Тузгыган, таралган. *Тәрәзәдән кергән кояш яктысы гүя аны назлый, иркәли, пришан чәчләреннән, озын керфекләреннән сыйпый.* Ш. Камал.

ПРИЮТ *и.* Патша Россиясендә ятим яки тәрбиячесез калган балаларны тәрбияләү учреждениесе; балалар йорты. *Приют баласы.* □ *Ул вакыттагы приют --- тәмсез ашлары, шыксыз бүлмәләре, караңгы, салкын ятаклары, пычрак ишек аллары, каты режимы белән, тәрбия йорты булудан бигрәк, патша төрмәсенә охшый [иде].* Г. Гобәй. *— Приюттагы балам ничек тора икән?.. Әй мескен! Үсәрсең, як-ягыңа әйләнеп карарсың, әмма атаң берлә анаңны таба алмассың!* Г. Коләхметов.

ПРО'БА *и. сөйл.* **1.** Берәр нәрсәнең анализ, тикшерү, сынау өчен алынган бер өлеше. *— Азык лабораториясе өчен пробалар алып кайтырмын, карармын, тикшерермен.* А. Расих. *Чан түбәсенә менеп, пробага нефть алып төшәм.* М. Хәбибуллин.

2. Эретмәдә алтын-көмеш өлешенең микъдары; шундый эретмәләрдән ясалган алтын, ак алтын, көмеш әйберләрдә шул микъдарны күрсәтә торган келәймә. *Проба сугу. Туксан алтылы проба.*

ПРОБИ'РКА *и.* Лаборатория эшендә кулланыла торган бер башы йомык пыяла көпшә. *Өстәлдә химия әсбаплары: пробирка, шешәләр.* Ш. Камал. *[Зөлфә] пробирка астына китереп, аңардан әлеге шәмәхә төсендәге эремәле колбага аксыл-соргылт сыекчаны --- агызырга тотынды.* Э. Касыймов.

ПРО'БКА *и.* Электр саклагычының бер төре. *Лампочка бозылганмыдыр, пробка янган булганмыдыр, күзәнә төртсәләр дә күренмәслек караңгы.* М. Әмир.

ПРОБЛЕ'МА *и.* Хәл ителергә тиешле теоретик яки практик мәсьәлә. *Проблеманы чишү. Кадрлар проблемасы. Актуаль проблема. Социаль проблема.* □ *Революциягә кадәр булган иске тормыштагы семьяда каениш, бигрәк тә килен белән каенана мәсьәләсе зур проблема булып торадыр иде.* М. Гали. *— Мин химия буенча яңа проблема өстендә эшлим.* Ш. Камал.

ПРОБЛЕ'МАЛЫ *с.* Берәр проблеманы тикшерүгә, хәл итүгә багышланган, берәр проблеманы күтәреп чыккан. *Проблемалы мәкалә.*

ПРОБЛЕ'МАЛЫЛЫК *и.* Проблемалы булу. *Проблемалылыкны теге яки бу кимчелекләрне, җитешсезлекләрне ачу белән генә бәйләп карау мәҗбүри түгел.* Р. Мостафин.

ПРОБЛЕМА'ТИК *с.* Берәр проблеманы тикшерүгә, чишүгә багышланган; берәр проблеманы чишү, тикшерү белән бәйле. *„Саз чәчәге" повесте, проблематик әсәр буларак, тормыштагы хәл ителергә тиешле мәсьәләләргә безнең игътибарны юнәлтергә, уйланырга, фикер йөртергә мәҗбүр итә.* И. Нуруллин. *[Тәнкыйтьчеләребез] бүгенге әдәби вакыйгаларны системалаштырып, проблематик планда анализларга омтылалар.* З. Мәҗитов.

ПРОБЛЕМА'ТИКА *и.* Проблемалар җыелмасы. *Фәнни эш проблематикасы.* □ *[Күргәзмәдә] Татарстан сынлы сәнгатенең төп проблематикасы шактый тулы чагылды.* Каз. утл.

ПРОБЛЕМА'ТИКЛЫК *и.* Проблематик булу.

ПРОВАНС: прованс мае — зәйтүн мае.

ПРОВАНСАЛЬ *и. махс.* Йомырка сарысына үсемлек мае, бераз серкә, горчица һ. б. кайбер аш тәмләткечләр салып ясалган соус.

Провансаль кәбестә — ваклап туралган тозлы кәбестәгә маринад, үсемлек мае һ. б. тәмләткечләр катнаштырып әзерләнгән ашамлык.

ПРОВИ'ЗОР *и.* Югары квалификацияле аптека хезмәткәре, фармацевт.

ПРОВИНЦИАЛ *и. иск.* Провинциядә (4 мәгъ.) яшәүче кеше. || *сөйл.* (Түбәнсетү төсмере белән.) Провинциядә яшәүчеләргә хас гадәтләре, сыйфатлары булган кеше; тар карашлы кеше. *— Бу үзенең фантазиясе белән күгәрчен оясыннан узалмаган провинциал иптәш белән провинциал булып сүз көрәштереп торасым килми.* Ә. Фәйзи.

ПРОВИНЦИАЛИЗМ *и. лингв. иск. к.* диалектизм. *Тел байлыгыбызны арттыру, әдәби телебезне эластик формалар белән баету өчен, безгә мотлак провинциализмнардан файдаланырга кирәк.* С. Җәләл. *Тел мәсьәләсендә [Г. Камал] провинциализмнан ерак тора.* М. Гали.

ПРОВИНЦИАЛЬ *с.* **1.** *иск.* Провинциядә (4 мәгъ.) яши, провинциядә тора торган; провинциядә эшли торган. *Минем янга ул вакытта билгеле булган провинциаль актёр П. Н. Орлёнов килде.* З. Солтанов. *— Миңа сезнең менә бу провинциаль тормыш [кызыксыз]! Романтика юк монда!* Ә. Фәйзи.

2. *күч. кимс.* Беркатлы, хәйләсез (кеше турында). *Үз нәүбәтендә Нагиев та тәкәллеф күрсәтү ягыннан провинциаль сәүдәгәрдән калышмый иде.* Ф. Хөсни.

ПРОВИ'НЦИЯ *и.* **1.** *тар.* Борынгы римлылар тарафыннан басып алынган һәм Рим баскагы идарә иткән өлкә, ил.

2. *тар.* XVIII гасыр Россиясендә административ-территориаль берәмлек, губернаның бер өлеше.

3. Кайбер илләрдә административ-территориаль берәмлек. *[Ул аларны] Шәньси, Ганьсу, Нинся провинцияләренә алып килгән.* А. Шамов. *Автобус безне илнең көньягына — Сианүквиль провинциясенә алып китте.* Каз. утл.

4. *иск.* Илнең башкаласыннан ерак булган җир, өлкә, периферия. *Патша хөкүмәте Крыловны Петербургтан куа; --- Крылов берничә ел провинциядә әдәбияттан һәм матбугаттан аерылып яшәргә мәҗбүр була.* К. Нәҗми. *Үзәк шәһәрләр белән провинция арасында аерма кими баруын һәр адымда күрү куандыра.* С. Рафиков.

ПРОВИНЦИАЛЬЛӘШҮ *ф.* Тар карашлы, үз интереслары белән генә яшәүче кешегә әверелү.

ПРОВИТАМИН *и. биол.* Хайван организмында витаминнар барлыкка китерә торган матдә. *Үсентеләр яшел төскә керсәләр, азык каротинга — А провитаминына байый.* А. Расих.

ПРОВОДНИК *и.* Вагонда чисталык, тәртип саклаучы тимер юл хезмәткәре. *Тимер юлчылар формасы кигән мыеклы проводник билетларны ачу китергеч дәрәҗәдә вәземләп, озаклап тикшерде.* Г. Ахунов. *Вагон ишекләре ачылды, проводниклар күренде, алар артыннан --- пассажирлар төшә башлады.* Г. Мөхәммәтшин.

ПРОВОКА'ТОР *и.* **1.** Яшерен оешма членнарын полициягә (гестапога һ. б.) тотып бирер өчен, шул оешмага үтеп кергән агент. *Оешмага провокатор сырышкан булган, ул байтак кешене саткан.* Г. Әпсәләмов. *— Әлэктеңме, провокатор! Күпмегә саттың син безне?* К. Нәҗми.

2. Коткы таратучы, коткы салучы, провокация ясаучы. *— Кулаков вә башкалар үзләренең провокаторлары аша сезнең арагызда төрле язулар тараталар.* А. Расих.

ПРОВОКА'ТОРЛЫК *и.* Провокатор булу. — *Моның өчен провокаторлык сәясәтен генә аңларга кирәк!..* З. Бәширн.

Провокаторлык итү — провокация белән, коткы тарату белән шөгыльләнү, яшерен оешма членнарын полициягә һ. б. тоттыру. — *Бер кешегә генә әйтсәң дә, бөтен конспирацияне харап итәрсең, беләмсең, син провокаторлык иткән кебек буласың.* Г. Ибраһимов.

ПРОВОКАЦИОН *с.* Асылда провокация булган, провокация максаты белән эшләнгән. *Провокацион сорау. Провокацион чыгыш. Провокацион сүзләр.* □ — [*Моның*] *бары контр мулла-мунтагайлар чыгарган бер провокацион уйдырма булуын әче генә итеп язып бирерсең.* Ә. Еники. — *Осиповның Мәскәүгә җибәргән провокацион телеграммасы егерме дүрт сәгать эчендә ялганга чыгарылырга тиеш.* Ш. Усманов.

ПРОВОКА'ЦИЯ *и.* 1. Аерым кешеләрне, кешеләр төркемен, оешмаларны, илләрне авыр, хәтта һәлакәт китерерлек эшләргә котырту, өндәү; коткы. *Провокация ясау. Провокациягә бирелү.* □ *Уолл-стрит магнатлары тынычлыкны бозу һәм яңа сугыш утын дөрләтеп җибәрү өчен нинди генә мәкерләр, хәйләләр, провокацияләр уйлап чыгармадылар!* Ш. Мөдәррис. *Мин бу тамашаның провокация максаты белән алдан уйлап оештырылган икәнен төшенмәгән булыр идем, бәлки.* С. Баттал. || Полиция яшерен агентларының революцион оешмаларны зәгыйфьләндерүгә, таркатуга, тар-мар итүгә китерә торган хыянәтчел эшләре. — *Син шуңа ышанасыңмы? Провокация бит ул!..* Ш. Маннур.

2. *мед.* Авыруны ясалма рәвештә кузгату, көчәйтү.

3. *а.-х.* Орлыкның шытуын ясалма рәвештә тизләтү.

ПРОВОКА'ЦИЯЛЕ *с. к.* провокацион. *Коммуна кешеләре аңар ялган, провокацияле хәбәр дип карадылар.* Ш. Камал.

ПРОВОКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Провокация (1 мәгъ.) ясау. — *Тапсыннар, белсеннәр, нинди кабахәт провокацияли икән аны.* А. Расих.

ПРОГИМНА'ЗИЯ *и. тар.* Патша Россиясендә тулы булмаган урта мәктәп. — *Безнең гимназия һәм прогимназияләр кучер, лакей, кухарка --- балаларыннан тәмам арыначак!* Р. Ишморат. *Татар учительский школасында уку курсын бетереп чыгучылар --- прогимназияләрнең уку курсларын бетереп чыгучыларга бирелә торган хокуклар белән файдаланалар.* М. Гайнуллин.

ПРОГНОЗ *и.* 1. Фәнни мәгълүматлар нигезендә берәр вакыйганың, эш-хәлнең, күренешнең үсеше һәм булачак нәтиҗәсе турында алдан әйтеп кую. *Прогноз ясау. Прогноз кую.* □ [*Сарьянның*] *әйбәт повесть язачагына бик үк ышанып җитми идек. „Әткәм һөнәре“ безнең прогнозны челпәрәмә китерде.* Г. Ахунов.

2. Метеорологик мәгълүматларга таянып, киләчәк көннәрдә һаваның ничек булачагын алдан билгеләү. || Шундый мәгълүмат. *Тора-бара һавалар бюросының район үзәгеннән бирелә торган прогнозларны да телефон аркылы ул үзе кабул итә башлады.* Г. Галиев.

3. *мед.* Авыруның ничек узуына карап аның ни белән бетүен алдан әйтү.

ПРОГНОЗЧЫ *и.* Һаваның яки суның киләчәк көннәрдә ничек буласын алдан билгеләү, прогноз (2 мәгъ.) төзү белән шөгыльләнүче метеоролог.

ПРОГРАММ *с.* Программаны (1—2 мәгъ.) чагылдыра, аңлата торган; программа сыйфатындагы. *Программ документ.* □ *Һ. Такташ бу программ мәкаләсендә социалистик реализм принципларының татар совет әдәбиятында иҗади үстерелүе мәсьәләсен теоретик фикерләү һәм әдәби иҗат практикасы яктылыгында куйды.* Х. Хәйри.

ПРОГРА'ММА *и.* 1. Киләчәк эшләрнең, эшчәнлекнең планы. *Авыл хуҗалыгын күтәрү программасы.* □ — *Безнең заводның быелгы эшләп чыгару программасы былтыргыга караганда егерме биш процентка артык булырга тиеш.* Ш. Камал. *Аның исәбе үзенчә ферманың хәлен яхшырту өчен конкрет чараларлан торган зур бер программа төзү иде.* Ә. Еники.

2. Машина, станок һ. б. ш. җайланмалар кеше катнашыннан башка, автоматик рәвештә эшләсен, хәрәкәт итсен өчен, аларга бирелгән, салынган эш-хәрәкәт планы. *Электрон-исәпләү машинасына программа бирү.* □ *Бала бит ул алдан билгеләнгән программа белән эшли торган кибернетик машина түгел.* Л. Ихсанова. — *Автоматка без программа бирербез, ягъни аны өйрәтеп куярбыз.* А. Тимергалин.

3. Политик партия, дәүләт власте үзәк органының, җәмәгать оешмасының яки дәүләт, җәмәгать эшлеклесенең билгеләгән максатларын, бурычларын, киләчәктәге эшләрен эченә алган, бу эш принципларын аңлатып биргән документ. *КПСС программасы. Хөкүмәт программасы.* □ — *Татар хезмәт ияләре фәкать безнең большевиклар партиясенең җитәкчелеге астында гына, башка изелгән милләтләр белән берлектә, үзенең Милли Автономияле Республикасын төзиячәк. Бу — безнең программабыз.* Т. Гыйззәт. *Баш министр --- думада хөкүмәтнең программасын укыды.* Урал. [*Такташ*] *үзенең „Җир уллары“ трагедиясенә язган сүз башында, шигырь язуда үз программасын аңлата.* Г. Нигъмәти.

4. Берәр җыелышны, эшне, кичәне һ. б. ш. уздыру планы, тәртибе. *Съездның эш программасы. Бәйрәм кичәсенең программасы.*

5. Концертта, циркта һ. б. куела, уйнала торган әсәрләр, номерлар җыелмасы; радио, телевидение тапшыруларының планы. *Концерт программасы.* □ *Бу көн тапшырулар программасына Якуп Сәйфинең чыгышы да кертелгән.* Э. Касыймов. — *Безнең программабызда спектакльлардән тыш концерт номерлары да бар.* Х. Сәлимҗанов. || Уйнала торган әсәрләр һәм шул әсәрдәге рольләрне башкаручыларның исемлеге; шулар язылган (басылган) кәгазь. *Театр программасы.* □ *Имам әфәнде, кулына уен программасын тотып, хәзрәткә* [*кайбер*] *нәрсәләр сөйләп утыра.* Ф. Әмирхан. — *Программада: мәшһүр җырчы Адамантов җырлаячак, дип язылган.* Г. Камал.

6. Уку йортында укытыла торган фәннең кыскача эчтәлеге һәм методологик күрсәтмәләре бирелгән аңлатма. *Химия буенча программа. Алтынчы класс өчен татар теле программасы.* □ [*Укытучының*] *программасы бар, шуны кыш буе билгеле бер тәртип белән узасы, балаларга әллә ничаклы нәрсәләр сөйлисе, өйрәтәсе бар.* Г. Кашшаф. *Солтан балаларны программага кермәгән ике әсәр белән таныштырды.* Г. Кутуй. || Берәр уку йортында, факультетта, курста укытыла торган фәннәрнең барысы. *Физика-математика факультеты программасы. Югары уку йорты программасын үзләштерү.* □ *Урта мәктәп программасы буенча хәзерләнергә тотынсаң, күпме* [*вакыт*] *кирәк.* Г. Ибраһимов. — *Син юкка гына гимназия программасы белән хәзерләнеп ятасың.* Ф. Әмирхан.

7. Музыка әсәренең темасы, сюжеты. [*Симфоник поэманың*] *төп программасы итеп Кави Нәҗминең „Язгы җилләр“ романындагы вакыйгаларны, бигрәк тә соңгы кузгалышны алдым.* А. Вәлиуллин. *„Сүзсез җыр“, „Сагыш“, „Уйлану“ кебек исемнәр инструменталь музыканың эчтәлегенә бер төрле дә программа*

бирмиләр, ә бары әсәрнең күңел кәефен генә билгелиләр. Ж. Фәйзи.

ПРОГРА'ММАЛАУ *ф. мат.* 1. Электрон-исәпләү машиналарында математик яки логик мәсьәләләрне чишү өчен махсус код ярдәмендә программа (2 мәгъ.) төзү.

2. Электрон-исәпләү машиналарына, автомат станокларга һ. б. программа (2 мәгъ.) бирү.

ПРОГРА'ММАЛЫ: программалы идарә — бирелгән программа (2 мәгъ.) буенча автоматик рәвештә алып барыла торган идарә. **Программалы музыка** — билгеле бер темага язылган яки берәр сюжетка корылган инструменталь музыка (мәсәлән, симфоник поэма, увертюра). *Программалы музыкалар, сүзсез булуларына карамастан, билгеле бер сюжетка корылган булулары белән, башка төр зур күләмле музыка әсәрләренә караганда, аңлаешлылар.* Ж. Фәйзи. *Музыканың программалы дип аталуы ук аның билгеле бер эчтәлеккә, программага корылуы турында сөйли.* А. Вәлиуллин.

ПРОГРА'ММАЛЫЛЫК *и.* Программалы булу. *Музыкадагы программалылык Листны, барыннан да бигрәк, чын демократизм элементлары туплаган жанр буларак үзенә тарта.* Сов. әд.

ПРОГРЕСС *и.* Үсеш процессында алга бару, түбәнге баскычтан законлы рәвештә үсешнең югарыгы баскычына күчү, камилләшү. *Артта калды Прогресска таяк тыгар чак.* Ш. Мөдәррис. — *Без таркау яшибез, Ибраһим әфәнде. Ә безнең прогресс өчен нинди кирәк мондый җыелулар!* Ә. Фәйзи.

ПРОГРЕССИВ *с.* 1. Акрынлап үсә, арта, көчәя бара торган; пропорциональ рәвештә үсә торган. *Прогрессив түләү системасы.* □ *РСДРП тугрыдан түләнми торган налогларның бетүен һәм доходка, мираска карап үсә торган (прогрессив) налог куелуын сорый.* РСДРП прокламациясе.

2. *к.* алдынгы (3 мәгъ.). *Прогрессив кешелек дөньясы. Прогрессив идея.* □ [*Руханилар*] *һәрбер прогрессив омтылышны буарга, кысарга теләделәр.* М. Җәлил. *Шәрык клубы --- прогрессив яшьләрнең оешкан төстә искелеккә, фанатизмга каршы хәрәкәт итүләренең үзәге булып килде.* И. Рәмиев.

ПРОГРЕССИ'ВКА *и. сөйл.* Нормадан тыш эшләнгән продукция өчен әйбер санының артуына карап акрынлап өстәлә торган бәяләр системасы буенча түләү (хезмәт хакын эш башыннан түләүнең бер төре). *Командага эш хакы биреп бетердем, әмма сезнең энекәшегез Харис прогрессивкасын алмады.* С. Сабиров.

ПРОГРЕССИВЛЫК *и.* Прогрессив булу. [*Элек*] *прогрессивлык, демократлык идеяләрен күтәреп чыгучыларга яшәү мөмкинлеге бирелм*[*әде*]. М. Гали.

ПРОГРЕССИСТ *и. кит. к.* прогрессчы. — *Үзен прогрессистлар арасында санаганга, газета мөхәррирләренә ачуланып хатлар яза торган чиновниклар --- һәммәсе шул мирзалар арасыннан чыккан.* Ф. Әмирхан.

ПРОГРЕ'ССИЯ *и. мат.* Теге яки бу тәртиптәге саннар рәтенә даими бер санны кушып бару нәтиҗәсендә (арифметик прогрессия) яки даими бер санны тапкырлау нәтиҗәсендә (геометрик прогрессия) барлыкка килә торган саннар рәте. *Арифметик прогрессия* (мәсәлән, даими сан 2 булганда: 1, 3, 5, 7... яки 2, 4, 6, 8...). *Геометрик прогрессия* (мәсәлән, даими сан 2 булганда: 1, 2, 4, 8, 16, 32...). *Прогрессия аермасы.* □ *Әгәр кысылу процессының тизлеге геометрик прогрессия буенча артса, кешелек дөньясының гомере --- кимрәк калган дигән сүз!* А. Тимергалин.

ПРОГРЕССЧЫ *и.* Прогресс тарафдары. [*Шәмигулов*] *үзен һәрвакыт мәгърифәтчел, прогрессчы итеп күрсәтергә тырышкан.* З. Бәширн.

ПРОГУЛ *и. сөйл.* Сәбәпсез эшкә чыкмау, эштән калу. — *Бер прогул да ясамаска, чын ударникларча эшләргә шахтёрларча сүз бирәбез.* Һ. Такташ. — *Прогул өчен сине заводтан, әлбәттә, үкчән күтәртергә кирәк.* И. Гази.

ПРОГУЛЧЫ *и. сөйл.* Сәбәпсез эшкә чыкмаучы, эш калдыручы кеше; прогул ясаучы кеше. [*Указ*] *прогулчыларга каршы юнәлтелә.* М. Җәлил.

ПРОДНАЛОГ *и.* 1921—1923 елларда: авыл хуҗалыгы продуктларын натуралата түләү.— *Партиянең мартта булып үткән унынчы съездында продразвёрсткадан продналогка күчү турында чыгарган карары исеңдәме?* Ш. Камал.

ПРОДОТРЯД *и.* Хәрби коммунизм чорында продразвёрстка буенча азык-төлек җыеп йөрүче эшче-крестьяннардан торган кораллы отряд; азык отряды. *Кулаклар Галимҗан хәзрәт малае дхмәт поручик җитәкчелегендә авылга килгән продотрядны туздырып, фетнә кубарып йөргән*[*нәр*]. Э. Касыймов.

ПРОДОТРЯДЧЫ *и.* Продотряд члены. [*Без*], *коммунистлардан ундүрт продотрядчы, Арып-Балык станицасына юнәлдек.* И. Салахов. [*Кулак*] *Сәлмән карт, хаты саен диярлек, контрибуцияләрнең күплегеннән, продотрядчыларның катылыгыннан --- зарланып яза.* Ф. Хөсни.

ПРОДРАЗВЁРСТКА *и.* Хәрби коммунизм чорында (1919—1921 елларда): барлык артык игенне мәҗбүри рәвештә дәүләткә тапшыру; шул турыда дәүләт заданиесе. [*Ул*] *Кызыл Армиягә язылып, хәзер инде өяз шәһәрендә продразвёрстка отрядының башлыгы булып эшли.* Һ. Такташ. *Авылга продразвёрстка килгәч, иң элек развёрстканы түләп бетерүче Сәмигыл абзый булды.* М. Гали.

ПРОДУКТ *и.* 1. Кеше хезмәте, кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйбер, матдә һ. б. *Авыл хуҗалыгы продуктлары. Продуктлар җитештерү һәм бүлү.* □ *Терлекләрнең продукт бирүләрен арттыруда, азык әзерләүдә --- көчне дә, акчаны да жәлләмәскә кирәк.* Ә. Еники.

2. Икенче бер матдәдән химик яки башка юл белән табылган матдә. *Керосин, бензин — нефть продуктлары.*

3. Азык-төлек, азык. *Мин* [*теләсә нинди*] *продукттан бик шәп итеп төрле ашлар пешерә беләм.* Ш. Усманов. — *„Ара"ның продуктлар төре күп түгел ич, — диде дхмәт, — какао, кукуруз ярмасы, маргарин, тагын нәрсә соң?* Ш. Камал.

Продуктлар алмашу — авыл хуҗалыгы һәм промышленность товарларын сәүдәсез алмашу.

ПРОДУКТИВ *с.* 1. Файдалы, нәтиҗәле. *Җитештерүнең продуктив ысуллары. Продуктив хезмәт.*

2. Терлекчелек продуктларын күбрәк бирә торган. *Кошларның продуктив төрләре. Продуктив азык.*

3. *лингв.* Хәзерге вакытта киң таралган, яңа сүз һәм сүз формалары ясауда еш кулланыла торган; актив. *Продуктив кушымча* (мәсәлән, *-чы, -че* кушымчасы). *Сүз ясалышының продуктив төре.*

ПРОДУКТИВЛЫК *и.* 1. Продукция бирү сәләте (терлекләр, кошлар турында).

2. *лингв.* Продуктив (3 мәгъ.) булу. *Продуктивлыгын югалткан кушымчалар хәзерге телдә яңа сүз ясамыйлар.* Д. Тумашева.

ПРОДУ'КТЛАТА *рәв.* Продукт (1, 3 мәгъ.) рәвешендә, азыклата. *Авыруы көчәю аркасында санаторийга бара алмаганда, путёвкага тиешле паёкны продуктлата аның өенә китерәләр иде.* Г. Ибраһимов

тур. ист. || *с. мәгъ.* Продукт рәвешендә булган. *Продуктлата рента.*

ПРОДУ'КТЛЫ *с.* 1. Кайбер сыйфатлардан соң килгәндә: продукциясе шул сыйфат белдергәнчә була торган. *Югары продуктлы культура. Түбән продуктлы.*

2. Эзләнелә торган продукты (1 мәгъ.), чималы булган, продуктив. *Борау продуктлы горизонтка җитеп килә.* Ш. Бикчурин.

ПРОДУ'КТЛЫЛЫК *и.* Продукция бирү сәләте (терлекләр, кошлар турында). *Терлекләрнең нәселен яхшырту, баш санын арттыру, продуктлылыгын күтәрү --- җитәкчелек осталыгына бәйләнгән бит.* Каз. утл.

ПРОДУКТҮТКӘРГЕЧ *и.* Нефть продуктларын нефть чыккан җирдән химия заводына кудыру өчен трубопровод. *Әлмәт—Казан продуктүткаргече.*

ПРОДУ'КЦИЯ *и.* Билгеле бер вакыт арасында берәр предприятие, промышленность тармагы яки илнең бөтен халык хуҗалыгы җитештереп чыгара торган әйберләр җыелмасы. *Фабриканың еллык продукциясе. Промышленностьның тулаем продукциясе.* □ *Заводта дистәләгән цех бар, чыгарылган продукцияләрнең төре утыздан артып китә.* Э. Касыймов. *— Минем бригада, әйтик, йөз илле процент иң яхшы сыйфатлы продукция бирә.* Р. Ишморат. || Эшләп чыгарылган, җитештерелгән аерым әйбер. *Дзер продукция. Эшләп чыгарылган продукциянең сыйфаты. Продукциянең үзкыйммәтен төшерү.* □ *— Сәламәтләнә төшкәч, заводыгыз эшләп чыгара торган продукциянең чертёжын [бирерсез].* Г. Гобәй. || Сәнгать, әдәбият әсәре, фәнни әсәр. *1900—1916 еллар дәвамында нәшрият көнчыгыш телләрендә чыккан басма китап продукциясенең өчтән бер өлешен үз кулында тотып килә.* И. Рәмиев. [*Г. Камалның*] *тәрҗемәчелек продукциясенең иң күп өлешен әдәби тәрҗемәчелек түгел, гади тәрҗемәчелек алып тора.* М. Гали.

ПРОЕКТ *и.* 1. Берәр корылманың, төзелешнең, әйбернең алдан төзелгән язма планы, сызымы. *Йорт проекты. Электр станциясе проекты. Проектта күрсәтелгән егәрлек.* □ *— Проект буенча пар казаннары астында монолит бетон булырга тиеш.* А. Гыйләҗев. *Яңа салыначак ферманың проектын тикшерергә [кирәк].* Г. Гобәй.

2. *с. мәгъ.* Шундый планда каралган, шундый план белән билгеләнгән. *Көннәр утырып, язгы кояш карый башлаганда, борау забойга — проект тирәнлегенә якынлашты.* Ш. Бикчурин. || Берәр нәрсә проектлау, планлаштыру белән шөгыльләнә торган. *Проект бюросы.* □ *Бик кирәкле сызымнарны җибәргәннәре юк. Проект оешмаларына әллә кайчан сорап язган идек.* А. Гыйләҗев. *Трамвайдан төшкәч, каршы искән җилдән башын да капламыйча, проект институтына йөгерде ул.* М. Маликова.

3. Берәр нәрсә оештыру, төзү планы. *Мәктәп ачу проекты.*

4. Берәр документның расланганчыга кадәр фикер алышу, төзәтмәләр кертү өчен алдан төзелгән тексты. *Закон проекты.* □ *Мостафа үзе язган резолюция проектын укыды.* Ш. Камал. *Хәзергә проект рәвешендә эшләнгән тематик план шушы чыганакны күздә тота.* М. Җәлил.

ПРОЕКТАНТ *и.* Проект (1 мәгъ.) төзеп, аны яклаучы кеше.

ПРОЕКТИВ: проектив геометрия *мат.* — геометриянең билгеле бер үзәктән проекцияләгәндә үзлекләре үзгәрми торган фигураларны һәм җисемнәрне өйрәнә торган бүлеге.

ПРОЕ'КТЛАУ *ф. к.* проектлаштыру. *Әллә сез шәһәр үзәген мичнән башка гына проектлап бетердегезме?* М. Маликова. [*Б. Урманче*] *һәйкәлнең архитектура өлешен дә үзе проектлый.* Каз. утл.

ПРОЕ'КТЛАШТЫРУ *ф.* Проект (1 мәгъ.) төзү, проект әзерләү. *Химия заводын проектлаштыру. Балалар бакчасын проектлаштыру. Самолёт проектлаштыру.* □ *Бер мәртәбә проектлаштыргач, нигә инде тагын артык расход тотарга?* Г. Ахунов.

ПРОЕ'КТОР *и.* Берәр нәрсәнең зурайтылган сурәтен экранга төшерү өчен кулланыла торган яктылык приборы; проекцион аппарат. [*Нуров*] *атналар буе үзе төшергән киноленталарны проекторда карап өйрәнеп утыра.* А. Тимергалин.

ПРОЕ'КТЧЫ *и.* Проектлаштыру белән шөгыльләнүче, проект (1 мәгъ.) төзүче. [*Арслан*] *идарә проектчыларына моңарчы күрелмәгән яңа эш тапшырды.* Г. Ахунов.

ПРОЕКЦИОН: проекцион аппарат — *к.* проектор. *Бернинди оптик җиһазлардан — көзгеләр, линза һәм проекцион аппаратлардан башка, буш кул белән, моны --- Кио да эшли алмас.* А. Тимергалин. **Проекцион фонарь** — берәр нәрсәнең сурәтен экранга зурайтып төшерү өчен кулланыла торган оптик аппарат.

ПРОЕ'КЦИЯ *и.* 1. *мат.* Күләмле фигураларны яссылыкта бирү, сызым белән күрсәтү. *Кисемтәнең турыга проекциясе. Нокта проекциясе.* □ *Кәгазьгә фәкать аның проекциясен генә сызып була.* А. Тимергалин.

2. *махс.* Рәсемнәрне, сызымнарны, кинокадрларны оптик юл белән зурайтып экранга төшерү.

ПРОЕ'КЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Яссылык өстендә берәр фигураның, предметның сурәтен төшерү; проекция (1 мәгъ.) сызу.

2. *махс.* Экранга берәр рәсемнең, сызымның, кинокадрның зурайтылган сурәтен төшерү.

ПРОЖЕКТ *и. иск.* Проект, план. || *ирон.* Тормышка ашмаслык, нигезсез проект, план. *Нуров абзаң --- минем кебек йомшак бәндәләрне үз прожектларына катнаштыру өчен үгетли башлаячак.* А. Тимергалин.

ПРОЖЕКТЁР *и. ирон.* Тормышка ашмаслык, нигезсез проектлар төзү белән мавыгучы кеше.

ПРОЖЕКТЁРЛЫК *и.* Тормышка ашмаслык, нигезсез планнар төзү белән мавыгу. *Бу фикернең практик нигезе юк, алдан ук уңышсызлыкка дучар ителгән сафсата, прожектёрлык бу!* А. Гыйләҗев.

ПРОЖЕ'КТОР *и.* Көчле яктылык чыганагыннан һәм зур батынкы көзгедән гыйбарәт яктылык приборы (бу көзге үзенә төшкән яктылык нурларын билгеле бер юнәлештә бәйләм итеп җибәрә). *Капка башында прожектор утлары кабына. Аларның нурлары, ак елан кебек, ишек алдына, бина стеналарына кинәт кенә сузылалар.* Н. Дәүли.

ПРОЖЕ'КТОРЧЫ *и.* Прожектор белән эш итүче белгеч.

ПРО'ЗА *и.* 1. Чәчмә сөйләм; шигъри (1 мәгъ.) булмаган сөйләм. *Проза белән язылган әсәр.* □ *— Андый сөйләшүләрне проза белән язу яхшы.* М. Җәлил. *Проза белән сөйләп бара торгач, Сәгъди шигырьгә күчеп китә, аннан тагын прозага кайта.* Х. Госман. || Чәчмә әсәрләрдән торган әдәбият; сөйләмнең чәчмә төре белән язылган матур әдәбият әсәрләре. *Проза теле.* □ *Тукай соңгы елларда Гейне белән нык кызыксынган, кайбер шигырьләрендә, аеруча прозасында Гейнега ияреп [күренгәли].* Г. Нигъмәти. *Татар әдәби телен эшләүче бу ике гигант [Г. Камал һәм Г. Тукай] — берсе проза өлкәсендә, икенчесе поэзия өлкәсендә — гомерләренең ахырына кадәр бер-берсе белән ярышып эш алып баралар.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Сөйләмнең чәчмә төре белән язылган; прозаик II (1 мәгъ.).

Проза әсәрләренең телен тикшерү. □ *Проза әсәрләреннән И. Газиның „Алмагачлар чәчәк ата“, Ф. Хөснинең „Җәй башы“ повестьлары, Д. Еникинең „Кышкы юлда“ исемле хикәясе укучылар тарафыннан җылы каршы алынды.* Г. Гобәй.

2. *күч.* Көндәлек тормыш; тормыш өчен кирәкле, гадәти нәрсә. *Һәрвакыт һәркемнең күз алдында җәелеп, таркалып яткан тормыш „прозасы“на татар поэзиясендә тулы хокук бирелде.* Г. Халит. — *Монда гы „поэзия“не ташлап, тагы шул „проза“га — эчпошыргыч тормышка кайтырга кирәк.* Ә. Фәйзи.

ПРОЗА'ИК I *и.* Чәчмә әсәрләр, проза әсәрләре язучы. *Тукай, Гафурилар талантлы шагыйрьләр генә түгел, оста прозаиклар да булганнар.* Н. Юзиев.

ПРОЗА'ИК II *с.* **1.** Проза (1 мәгъ.) белән язылган. *Прозаик әсәрләр.*

2. Прозага (1 мәгъ.) хас (булган), шигъри булмаган, коры, төссез. *Прозаик әйләнмә.* □ *Поэтик бизәкләр дә төссезләндерелгән — башка прозаик сүз белән алыштырылган.* Г. Кашшаф.

3. *күч.* Көндәлек, гадәти, кызыксыз, эчпошыргыч (тормыш, көнкүреш турында). *Мине бәрәңге һәм итсөт дип аталган „прозаик“ әйберләр турындагы уйлар [басты].* Каз. утл.

ПРОЗЕ'КТОР *и. мед.* Мәетләр яру белән шөгыльләнүче врач.

ПРОЗЕ'КТОРЛЫК *и. мед.* Прозектор вазифасы, прозектор хезмәте.

ПРОИЗВО'ДСТВО *и.* **1.** Җәмгыять яшәеше өчен зарури булган материаль байлыклар җитештерү (процессы). *Производство технологиясе. Производство күәте.* □ *Хәреф җыю, басу, төплау, --- хәреф кою цехлары әре производство төсен ала.* И. Рәмиев. — *Производство акрынлап үсә, үзебезнең заводка күп кенә яңа машиналар килде.* Ш. Камал. || Продукция хәзерләү белән турыдан-туры бәйләнгән эш. *Скворцов Уралда эшче семьясында туып үскән, биш ел производствода эшләгән.* М. Гали. — [*Шамил*] *әтиләр белән бергә заводта эшли, производстводан аерылмыйча очучылар мәктәбендә укый.* Т. Гыйззәт. || Халык хуҗалыгының яки промышленностьның бер тармагы. *Металлургия производствосы. Текстиль производствосы. Авыл хуҗалыгы производствосы.* □ *Вәлишин дә үзенең шинель сукносы һәм күн эшкәртү производствосын киңәйтте.* К. Нәҗми.

2. *с. мәгъ.* Материаль байлыклар җитештерү процессы белән бәйле. *Производство практикасы.* || Берәр әйбер җитештерү белән шөгыльләнә торган. *Производство бригадасы.*

Производство киңәшмәсе — предприятие, учреждение хезмәткәрләренең, эшчеләренең производствога бәйләнгән мәсьәләләрне коллективта бергәләп хәл итү өчен җыелган киңәшмәсе. — *Өченче көн производство киңәшмәсендә безнең эшебезгә комачаулый торган моментларны тәнкыйть итеп чыккан идем.* Р. Ишморат. **Производство мөнәсәбәтләре** *экон.* — материаль байлыкларны ижтимагый җитештерү процессында кешеләр арасында барлыкка килә торган бәйләнешләр һәм мөнәсәбәтләр. *Бистә тормышына, политэкономия теле белән әйтсәк, яңа производство мөнәсәбәтләре керде.* Ә. Еники. **Производстводан аерылмыйча** — производствода эшләп.

ПРОКАТ I *и.* **1.** Прокатлау ысулы белән эшкәртелгән әйберләр. *Тимер прокат. Прокатны кисү.* || *с. мәгъ.* Әйберләр прокатлау белән бәйле. [*Мине*] *прокат цехына күчерделәр. Монда --- вак сортлы рельслар, --- йомры тимер-арматур* [*чыгарыла икән*]. Ш. Маннур.

2. *сөйл.* Прокатлау станы. *Метеордай кызган болванка Килеп кысыла прокат валына.* Ф. Кәрим.

ПРОКАТ II: **прокатка алу** — берәр нәрсәне билгеле бер хак белән вакытлыча файдалану. [*Пьесаны*] *сәхнәгә куяр өчен рус театрыннан прокатка махсус париклар, костюмнар алынды.* Сов. әд. *Ул прокатка алып куелган рояль янында утыра да сәгатьләр буе урыныннан купмый уйный иде.* Ш. Хөсәенов.

ПРОКАТЛАУ *ф. тех.* Металлны әйләнеп торган ике вал арасыннан үткәреп юкарту. *Тимер прокатлау.* || *с. мәгъ.* Металлны әйләнеп тора торган ике вал арасына кыстырып эшкәртә торган. *Кайнар хәлдә прокатлау станнарының подшипникларын --- пластмассадан ясау файдалырак булуы 1932 елда ук исбат ителгән иде.* Г. Камай.

ПРОКАТЧЫ *и.* Прокатлау белән шөгыльләнүче, прокат станында эшләүче эшче.

ПРОКЛАМА'ЦИЯ *и.* Агитация максаты белән таратыла торган политик эчтәлекле листовка. [*Хөсәен*] *кәгазьне җилемгә китереп каплады да, уклавын тәгәрәткәч, кәгазьне тагы куптарып алды: „Егетләр,— диде Хөсәен, яктырып, — прокламация менә дигән булып чыкты!“* А. Расих. [*Революционерлар*] *халыкны котыртып, хөкүмәткә зарарлы прокламацияләр тараталар.* Ш. Мөхәммәдев.

ПРОКУРАТУ'РА *и.* Законнарның дөрес үтәлешен күзәтү һәм закон бозучыларны җавапка тарту белән шөгыльләнә торган дәүләт органы. *Шәрәфи бу материалларның кайберен шул заманда Иванов аркылы прокуратурага озата барды.* Г. Ибраһимов. — *Миңа Казаннан прокуратурадан шалтыраттылар. Тангаровлар эшен туктатып торырга кушалар.* Һ. Такташ.

ПРОКУРОР *и.* **1.** Законнарның төгәл үтәлешен күзәтүче дәүләт хезмәткәре. *Район прокуроры. СССРның Генеральный прокуроры. Хәрби прокурор.* □ *Мөстәкыйлмне эшеннән алып, аның турындагы материалны прокурорга бирделәр.* А. Расих. *Прокурордан санкция алып, Зариф абзыйның йортына тентү кертте*[*ләр*]. Г. Гобәй.

2. Суд процессында дәүләт гаепләүчесе. *Прокурор трибунага баса. Ул бик дәһшәтле итеп башлаган гаеплау речендә Муса белән Алишны язучы маскасы астында Мәскәүдән яшерен җибәрелгән шпион-пропагандистлар итеп* [*күрсәтә*]. Ш. Маннур. *Прокурорның гаепләнүчеләргә нинди җәзалар бирергә тиешлеге турындагы сөйләгәннәре минуты-сәгате белән каланың урамнарына --- таралып өлгергән иде инде.* Г. Ибраһимов.

ПРОКУРОРЛЫК *и.* Прокурор вазифасы, прокурор хезмәте. — *Кичке мәктәпне бетергәч тә, прокурорлыкка укыячакмын.* Х. Вахит. *Минем рәсми прокурорлыгым социализм юлындагы идеяләремне гамәлгә ашыру өчен зур мәйдан гына ачачак.* М. Галәү.

ПРОЛЁТ *и.* **1.** Завод бинасында, цехта ике рәт баганалар, терәкләр арасындагы урын. *Төп корпусның беренче ике пролётын сафка кертү.* □ *Пролётларда бергә култыклашып шаулый-шаулый бетон таптаулар Онытылмаслар, гомер онытылмаслар.* Ш. Маннур.

2. Корылмаларның, күперләрнең ике терәк арасындагы өлеше. *Шундый киң дәрья аша җиңел челтәр төсле сузылган корыч пролётларның нәфислегенә сокланып бара*[*м*]. К. Нәҗми.

ПРОЛЕТАР *с.* Пролетарийларныкы булган. *Пролетар партия.* □ *Патшаны, завод хуҗаларын, алпавытларны һәм ак генералларны пролетар революция бәреп төшерде.* Г. Ахунов. || Пролетарийларга хас. *Пролетар бердәмлек. Пролетар оешканлык.* □ *Пьеса пролетар интернационализм идеясе белән сугарылган.* Г. Нигъмәти. || *и. мәгъ. сөйл.* Пролетарий. — *Мин бер пролетар баласы, этием — иске эшче,*

иске көрәшче, капиталистлар белән көрәшеп төрмәдә утырган. Ф. Сәйфи-Казанлы. *Ленин үлде... Тик ул һәр пролетар йөрәгендә туды яңадан!* Ә. Фәйзи.

ПРОЛЕТАРИАТ *и.* Капиталистик җәмгыятьтә үзләренең җитештерү чаралары булмаган һәм буржуазия тарафыннан эксплуатацияләнә торган яллы эшчеләр, пролетарийлар сыйныфы. *Бу [үзгәрешләр] пролетариатның (эшчеләр сыйныфының) кулына буржуазия сыйныфы белән көрәшергә яңа корал гына бирә.* Урал. *Большевиклар партиясе бөтен Петроград пролетариатын Корниловка каршы күтәргән.* И. Гази. || *с. мәгъ. к.* пролетар. *Пролетариат диктатурасы. Пролетариат демократиясе. Пролетариат дәүләте. Пролетариат культурасы. Пролетариат язучысы.* □ *Бу шигырьләр --- пролетариат революциясе дошманнарына карата ачы һәм үткен сатира белән сугарылган.* М. Гали. *Бүгенге пролетариат әдәбияты — ул безнең уйларыбызның хәрәкәте, идеяләребезнең омтылышы булырга тиеш.* Һ. Такташ.

ПРОЛЕТАРИА'ТЧА *рәв.* Пролетариатка хас. *[Без] гегемонлык алу бурычын --- пролетариатча тотнаклы, --- көчле әсәрләр тудырсак кына үти алырбыз.* М. Җәлил.

ПРОЛЕТА'РИЙ *и.* 1. Капиталистик җәмгыятьтә үз җитештерү чаралары булмаган яллы эшче. *Ярым пролетарий. Бөтен дөнья пролетарийлары, берләшегез!* □ *Унар мең пролетарийларны капитал авыллардан һәм кечкенә шәһәрләрдән зур шәһәрләргә тарта.* Урал. *Кайда эшчеләр берлә байлар, ягъни кайда пролетарий берлә буржуазия, ул җирдә хезмәтне талау бар.* РСДРП прокламациясе.

2. *тар.* Борынгы Римда ярлылар сословиесеннән булган граждан.

ПРОЛЕТАРЛАШУ *ф.* Капитализм шартларында вак товар җитештерүченең (мәсәлән, крестьян, вак һөнәрче һ. б. ш. ның) котылгысыз рәвештә бөлеп, мохтаҗлыкка төшеп, пролетарийга (1 мәгъ.) әверелүе. *Горький — шәһәр әдибе. Провинция шәһәренең купец, төрле тип мещан, вак буржуа пролетарлашуының төрле дәверендәге эшчеләр тормышын язган әдип.* Г. Нигъмәти.

ПРОЛЕТА'РЧА *рәв.* Пролетарларга хас булганча. *Пролетарча яшәү.* || *с. мәгъ. Пролетарча рәхмәт, Зөбәржәт ипташ.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ПРОЛЁТКА *и.* Ике урынлы, дүрт тәгәрмәчле, ачык җиңел тарантас. *Бикә абыстай кызын, --- сабакка барганда эче селкенмәсен дип, һәрвакытта йомшак пролёткага гына утыртып йөртә иде.* Г. Камал. *Алар, утыргычларындагы күннәре туналган пролёткага утырып, крепость капкасыннан кереп киттеләр.* К. Тинчурин.

ПРОЛЕТКУЛЬТ *и.* 1917—1932 елларда „лаборатория“ юлы белән пролетариат культурасы төзү турында ялгыш идеяләр үткәргән культура-агарту оешмасы.

ПРОЛЕТКУЛЬТЛЫК *и.* Пролеткультка хас идеяләр. *Пролеткультлык рухындагы аерым ялгышларына карамастан, [К. Нәҗми] эшчеләр сыйныфына хезмәт итә торган әдәбият һәм сәнгать барлыкка китерү мәсьәләләрен күтәргән иде.* Н. Гыйззәтуллин.

ПРОЛЕТКУЛЬТЧЫ *и.* Пролеткульт оешмасы члены, пролеткульт тарафдары. *Футуристлар һәм пролеткультчылар элекке культурага каршы көрәш лозунгысы белән кизәнделәр, бөтен мирасны инкяр итеп, нинди дер „саф пролетар культура“ төзү кирәклеге турында шау-шу күтәрделәр.* Г. Халит.

ПРОЛЕТКУЛЬТЧЫЛЫК *и.* Пролеткульт идеяләре, пролеткультчылар карашы. *20 елларда әдәбият белемендә, тәнкыйтьтә пролеткультчылык тамыр җәйгән иде.* И. Нуруллин. *Бездә кайбер яшь иптәшләр бөтен иске культураны, буржуаз культура ул дип, бөтенләй яраксызга чыгарырга телиләр. Күрәләтә ялгыш булган бу пролеткультчылыкны Ленин --- зур түземлелек белән тәнкыйтьли, аңлата.* С. Фәйзуллин.

ПРОЛОГ *и.* 1. Әдәби яки музыкаль әсәрнең, спектакльнең кереш өлеше. *Тукайның сабый чагы — [„Тукай“ либреттосының] прологы гына.* Н. Юзиев. *Прологта поручик Кузнецов роендә күренеп үткән Лутов әсәрдә үзәк треттан килгән корткыч инженер итеп гәүдәләндерелгән.* Г. Нигъмәти.

2. *күч.* Берәр нәрсәнең башлангычы. *Күпме яздым! Әмма китапларымның әллә ничә мең дистә юлы әйтергә теләгәнемә пролог кына.* Ә. Давыдов. *Әхмәт Фәйзи тарихи-эпик вакыйгалар, тарихи шәхесләр белән бик нык кызыксына башлый. „Качкын“ операсы либреттосы шагыйрьнең бу юнәлештәге зур эшенең прологы була.* Ф. Хөсни.

ПРОМКОМБИНАТ *и.* Шәһәр яки посёлоктагы вак предприятиеләр берләшмәсе — промышленность комбинаты. *Әти үз йортында бау ишүен ташлап, промкомбинатка эшкә күчкән. Шул ук бау эшенә.* Э. Касыймов. *Гыйлажи кайсыдыр промкомбинатта эшли.* И. Гази.

ПРОМТОВАР *и.* Көнкүреш өчен әһәмияте зур булган промышленность товарларының гомуми атамасы (мәсәлән, тукыма, кием, аяк киеме, трикотаж һ. б. ш.). || *с. мәгъ.* Шундый товарлар сата торган. — *Промтовар магазины директоры Сөнгатуллинны --- кисәтеп куярга кирәк.* Ә. Еники. *Кибетләрдә азыгы да, промтовар әйберләре дә күп.* Г. Әпсәләмов.

ПРОМФИНПЛАН *и.* Предприятиенең промышленность-финанс планы. — *Безгә бит промфинплан өчен көрәшергә кирәк.* Ш. Камал. *Шахтёрларның бүген йөрәгендә Промфинплан тутыру теләге.* Һ. Такташ.

ПРО'МЫСЕЛ *и.* 1. Җәнлек, кош, балык һ. б. ш. аулау предприятиесе яки предприятиеләр төркеме. *Кит аулау промыселы.* □ *[Ш. Камал] Каспий диңгезе буендагы балык промыселларында эшләп йөргән.* М. Җәлил. || *с. мәгъ.* Ауларга, тотарга яраклы; ит, май, йон бирә торган. *Промысел кошлары.*

2. Промышленность чималы табу предприятиесе яки предприятиеләр төркеме. *„Азнакайнефть“ промыселлар идарәсенең менә шушы дүртенче промысел егетләре чын-чыннан сокландырғыч уңышларга ирешеләр.* М. Хәсәнов. *Юллары бер аларның — колхоз авылына, нефть промыселларына таба.* Г. Минский. || *с. мәгъ.* Киң көнкүреш товарлары эшләп чыгара торган (вак предприятиеләр турында). *Промысел артеле. Промысел кооперациясе.*

ПРО'МЫСЕЛЧЫ *и.* Промысел эшчесе.

ПРО'МЫСЛО *и. сөйл. к.* промысел. *Гыйззәт промыслода эшләнеп беткән унбишәр потлы балык мичкәләрен бозлы базга тәгәрәтеп көнен уздыра.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Балык промыслоларында эш хакы яхшы була.* Ш. Камал.

ПРОМЫ'ШЛЕННИК *и.* Промышленность предприятиесе хуҗасы — капиталист. *Урман промышленнигы. Күмер промышленнигы.* □ *Питер һәм Мәскәү коммерсантлары, алтын промышленниклары Громовның приискаларын алу турында киңәшмә үткәрәләр.* Г. Ахунов. *Иске Россиянең политикасы мөселман промышленникларының аяк-кулын богаулап торды.* И. Гази.

ПРОМЫ'ШЛЕННОСТЬ *и.* 1. Халык хуҗалыгының җир асты казылмаларын табу һәм чимал эшкәртү белән шөгыльләнә торган предприятиеләрен берләштергән тармагы. *Эшкәртү промышленносте.* □ *— Безнең колхозларыбыз һәм совхозларыбыз да халыкны һәм Кызыл Армияне азык белән, промышленностебызны чимал белән намуслы һәм төгәл тәэмин итәләр.* Г. Бәширов. *XIX гасырның ахырында һәм XX гасыр-*

ның башында Россияне эченә алган промышленность кризисы эшчеләрнең хәлен тагын да начарландыра төште. М. Җәлил.

2. *с. мәгъ.* Нык үскән, көчле промышленносте булган. *Промышленность районы.* □ *Лена алтын прискаларында эшләүче эшчеләрне аттырулар Россияне төрле зур промышленность үзәкләрендә сәяси эш ташлаулар дулкынын тибрәндереп җибәрде.* Г. Нигъмәти. || Шундый предприятиеләрдә, халык хуҗалыгының шул тармагында эшли торган. *Промышленность эшчеләре. Промышленность пролетариаты.* || Шундый тармакка салынган. [*Сабитов*] — *Россиядә промышленность капиталы үсеп, --- татар сәүдә буржуазиясе арасында килеп чыккан яңару һәм җәдитчелек хәрәкәтенең вәкиле.* М. Гали.

3. Билгеле бер производство предприятиеләре. *Авыр промышленность. Җиңел промышленность. Авиация промышленносте. Агач эшкәртү промышленносте.* □ — *Илебезне индустияләштерү --- эшендә химия промышленносте чиксез зур урын тота.* Ш. Камал. *Театрда күмер промышленносте инженерларының Бөтенсоюз киңәшмәсе бара иде.* А. Шамов.

Промышленность капитализмы — капитализм үсешендә империализмнан элек булган һәм машина производствосы, ирекле конкуренция белән характерлана торган чор. *80 нче елларның бигрәк тә икенче яртысында ныкүсү юлына кергән промышленность капитализмы --- крестьяннарны бөлгенлеккә төшер*[*ә*]. Г. Нигъмәти.

ПРООБРАЗ *и.* **1.** Киләчәк өчен үрнәк, образ.

2. Әдәби персонаж тудыруда авторга үрнәк булып хезмәт иткән зат; прототип. *Казанда яшәүче һәм медицина эшчеләре белән беркадәр аралашучы ипташлар әсәрнең прообразларын азмы-күпме төсмерлиләр. --- Әмма иҗат эшендә иң кыены, иң авыры — прообраздан образга бару юлы.* Г. Әпсәләмов.

ПРОПАГАНДА *и.* **1.** Билгеле бер идеяне, тәгълиматны халыкка җиткерү һәм тирәнтен аңлату. *Техник пропаганда.* □ *Яшерен оешма лагерьлардан әсирләрнең качуын оештыра, фашистларга каршы пропаганда алып бара.* Г. Ахунов. — *Сез, агитаторлар, берәр җирдә дингә каршы пропаганданың әһәмияте турында бераз сөйләп җибәрсәгез* [*иде*]. Ш. Камал. || Киң массаларга политик характердагы идея тәэсире. *Империалистик пропаганда. Революцион пропаганда.*

2. *с. мәгъ.* Шундый идеяләрне, тәгълиматларны тарату эше белән шөгыльләнә торган. — *„Чулпан" тәҗрибәсен пропаганда бүлегенә --- агитаторлар семинарында файдаланырга* [*кирәк*]. Г. Бәширов.

ПРОПАГАНДАЛАУ *ф.* Пропаганда алып бару. *Коммунизм идеяләрен пропагандалау. Съезд карарларын пропагандалау.* □ [*Бакиров*] *бригаданың данлы юлын пропагандаларга тотына.* Р. Мостафин.

ПРОПАГАНДИСТ *и.* Берәр идеяне, тәгълиматны пропагандалаучы кеше. — *Сәйфелмөлеков белән без яшерен оешманың пропагандисты булып эшләдек. Совинформбюро сводкаларын легионерларга җиткердек.* Г. Кашшаф. *Алексей Петровичның пропагандист буларак бөтен осталыгы шунда: ул тыңлаучыларны уйланырга мәҗбүр итә.* Г. Әпсәләмов. || Лекция яки әңгәмәләрдә партия карарларын аңлатучы, политик түгәрәкләргә җитәкчелек итүче марксистик-ленинчыл партия члены. *Андый мәсьәлә турында Фәтхи ашыгып язса, аның нинди коммунист, нинди организатор һәм нинди пропагандист булуы мөмкин!* Ш. Камал.

ПРОПАГАНДИСТЛЫК *и.* Пропагандист булу; пропагандист эше. [*Газета*] *үзенең агитаторлык, пропагандистлык --- ролен намус белән үтәргә тырыша.* М. Максуд.

ПРОПАН *и. хим.* Ягулык итеп кулланыла торган органик кушылма (туендырылган углеводород). *Нефть газының пропан дигән фракциясе җылылык биреп кенә калмый, билгеле бер шартларда 42 градуска хәтле суыклык та бирә ала икән.* Г. Ахунов.

ПРОПЕДЕВТИКА *и.* Берәр фәннең кыскача башлангыч, кереш курсы. *Дәүбәкер Гәрәй улы Терегулов --- медицина институтында эчке авырулар пропедевтикасы кафедрасы мөдире* [*булып*] *эшли.* Соц. Тат.

ПРОПЕЛЛЕР *и.* Самолёт, аэрочана, глиссер һ. б. ш. ны хәрәкәткә китерә торган винт. *Бертуктамый зырлап әйләнеп торган пропеллер кинәт тынды.* А. Алиш. *Пропеллерның җиле мине артка каера.* С. Баттал.

ПРОПИЛЕН *и. хим.* Нефть эшкәртүндә чыга һәм техникада файдаланыла торган органик кушылма, газ.

ПРОПИСКА *и.* Кемнең дә булса билгеле бер урында торуын рәсмиләштерү; шул турыда документка (паспортка) ясалган билге. *Даими прописка. Пропискага керү. Пропискадан төшү.* □ — *Аннан соң, аларга фатирын да шундук бирәләрме, пропискага мәшәкатьсез кертәләрме?* Э. Касыймов. *Вакытлы прописка сроклары үткәч, сез мәрхүмәнең җизнәләрен --- чыгара аласыз.* С. Баттал.

ПРОПОЛИС *и. а.-х.* Бал кортлары ачылып килгән бөреләрдән җыеп, умартаның эченә, ярыкларга сылый торган сумалага бай матдә; тома балавыз.

ПРОПОРЦИОНАЛЬ *с.* **1.** Бер предмет кисәгенең, өлешенең үлчәве (күләме) икенчесенекенә карап зур яки кечкенә була торган. *Пропорциональ кисәкләр.* □ *Бер өчпочмакның өч ягы икенче, аңа караганда кечерәк өчпочмакның өч ягына пропорциональ.* Ж. Тәрҗеманов. || Пропорцияләре дөрес булган. — *Аның җыры ның эчтәлеге дә тавышының моңы белән пропорциональ рәвештә бара.* М. Гали.

2. *мат.* Бер зурлыкның кыйммәте зураюга (кечерәюгә) карап, икенче зурлыкның кыйммәте шулкадәр зурая (кечерәя) торган. *Туры пропорциональ. Кире пропорциональ.*

3. Пропорцияләрне, һәр тармакның үзара тигез бәйләнешен сайлауга нигезләнгән. *Халык хуҗалыгының пропорциональ үсеше.* □ *Думаларга халыктан вәкил сайлау һәр халыкның санына пропорциональ --- система берлән булган.* Х. Ямашев.

Пропорциональ циркуль — кисемтәне билгеле чагыштырмада киметү (яки арттыру), шулай ук аны берничә тигез кисәккә бүлү өчен кулланыла торган инструмент.

ПРОПОРЦИОНАЛЬЛЕК *и.* **1.** Пропорциональ булу сыйфаты.

2. *мат.* Пропорциональ рәвештә үзгәрә торган зурлыклар арасындагы үзара бәйлелек. *Туры пропорциональлек. Пропорциональлек коэффициенты.*

ПРОПОРЦИЯ *и.* **1.** Кисәкләрнең, өлешләрнең үзара чагыштырма бәйләнеше. || Нинди дә булса әйбернең аерым өлешләре, кисәкләре арасындагы микъдари бәйләнеш. *Күп кенә язучыларга пропорция тойгысы җитеп бетми.* И. Нуруллин. *Автор бу урында пропорция җебен бөтенләй ычкындыра.* Ф. Хөсни.

2. *мат.* Ике чагыштырманың үзара тигезлеге. *Арифметик пропорция. Геометрик пропорция. Өзлексез пропорция. Пропорция буыннары.*

ПРОПОРЦИЯЛЕ *с. к.* пропорциональ (1, 3 мәгъ.). [*Туфан*] *әсәрнең тышкы калыбы — формасы белән мәгънәсен пропорциялә бер матурлык белән төзә.* Г. Нигъмәти.

ПРОПО'РЦИЯЛЕЛЕК *и. к.* пропорциональлек. *Халык хуҗалыгын үстерүдә пропорциялелекне нык сакларга --- кирәк.* КПСС Программасы.

ПРО'ПУСК *и.* **1.** Бирәр урынга яки бинага керү өчен документ, рәсми таныклык. *Пропусклар системасы. Пропусклар бюросы.* □ *— Һичбер кешене пропускысыз үткәрмәгез, пропуск сорагыз.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. *к.* пароль. *Шәмси, пропускны әйтеп, часовойдан дивизия штабына юл сорады.* Г. Бәширов. — [*Часовойны*] *әле генә алыштырдылар. Пропускларын да белдем — „Прага".* Ә. Айдар.

ПРОРАБ *и.* Төзү эшләрендә турыдан-туры җитәкчелек итүче техник яки инженер. *Гәрәй белән көне буе төзелештә йөргән прораб Семён Михайлович Туркин төп Татарстан тумасы иде.* А. Гыйләҗев. *— Яхшы проект буенча матур биналар төзү безнең үзебезгә дә бик күңелле бит, — диде прораб.* М. Маликова.

ПРОРАБЛЫК *и.* Прораб булу, прораб хезмәте.

ПРОРАН *и.* **1.** *махс.* Елга яңа юнәлештә аксын өчен яр яки дамбаның җимерелгән өлеше.

2. *махс.* Шлюзлар эшли башлаганчы пароходлар йөрү өчен плотинада буылмый калган су юлы.

ПРОРЕ'КТОР *и.* Ректор урынбасары. *Кичке бүлек буенча проректор. Хуҗалык эшләре буенча проректор.* □ *Килүчеләр арасында институтның гыйльми эшләр буенча проректоры профессор Әсфәндияров та бар иде.* А. Расих. *Ике студент, Вахитовның шәхси делосы белән танышырга рөхсәт сорап, укыту эшләре буенча проректорга мөрәҗәгать итә.* Р. Нәфигов.

ПРОСПЕКТ I *и.* Гадәттә киң, туры, озын урам. *Г. Ибраһимов проспекты.* □ *Әлмәтнең үзәк урамы — тирәкләре белән шаулап утырган киң һәм якты Ленин проспекты — күренде.* Г. Ахунов. *Невский проспектка түшәлгән имән такталар, тугызынчы январь якшәмбесен хәтерләтеп, кан белән чыландылар.* К. Нәҗми.

ПРОСПЕКТ II *и.* **1.** Басылып чыга торган китап-журналның планы, кыскача эчтәлеге.

2. *к.* реклама (2 мәгъ.).

ПРОСТРА'НСТВО *и. филос.* Материя яшәешенең озынлык һәм күләм белән характерлана торган гомуми төп объектив формаларының берсе. *Чынбарлык объектив икән, димәк, ул бары тик пространствода гына (билгеле урын биләп кенә) яши һәм хәрәкәт итә ала.* М. Абдрахманов. *Пространствоның геометрик формалары материянең физик үзлекләренә бәйле.* Җ. Тәрҗеманов.

Пространстводагы кәкре *мат.* — барлык нокталары да бер үк яссылык өстендә ятмаган кәкре.

ПРОСТЫНЯ *и. сөйл. к.* җәймә I (1 мәгъ.). *Мин дә шундый үк бүлмәдә, шундый үк ак простынялар япкан кроватьта ятырмынмы?* Һ. Такташ. [*Кызылармеец*] *күлмәк, сөлге, простыня, сабын кебек нәрсәләрне капчыгына салган.* Ш. Усманов.

ПРОСЦЕ'НИУМ *и. театр.* Сәхнәнең пәрдә алдындагы өлеше. *Бөркет белән* [*Нәлли*] *алга, просцениумга чыгалар һәм биш-биш сөйләшәләр.* Р. Ишморат.

ПРОТЕЖЕ *и. кит.* Протекция белән файдаланучы, кемнең дә булса даими яклавы (канаты) астында булган кеше.

ПРОТЕЗ *и.* **1.** Ясалма аяк, кул, теш һ. б. *Бу юлы Ислам уң кулы урынына протез кигән өлгергән иде.* Ш. Хөсәенов. *— Минем аяклар үземнеке — протез түгел.* Ә. Фәйзи.

2. *с. мәгъ.* Сынган, киселгән аяк, кул, төшкән теш һ. б. урынына күннән, агачтан һ. б. ясалган. [*Мохтаров*], *диваннан торып, протез аягын шыгырдатып, өстәл янына килде.* Г. Ахунов. || Шундый ясалма аяк-куллар, тешләр ясый торган. *Протез мастерское.*

ПРОТЕ'ЗА *и. лингв.* Ике яки берничә тартыкка башланган чит сүзләр алдына әйтелештә сузык аваз өстәлү (мәсәлән, *ыстакан, өстәл, ыстина*). *Бөтен бер юлда, ритм таләбе белән яки орфоэпик норма буларак, --- сузык кыскару (синкопия) яисә өстәлү (протеза һәм парагогия) күренешләре килеп чыгарга мөмкин.* Х. Курбатов.

ПРОТЕЗЛАУ *ф.* Протез кую, протез белән тәэмин итү.

ПРОТЕЗЧЫ *и.* Протезлар ясаучы белгеч.

ПРОТЕИД *и. биол.* Гади аксымнар һәм аксым булмаган матдә кушылмасыннан торган катлаулы аксым. *Черемә составында күбрәк протеид (аксым) матдәсе булганлыктан, ул бөтенләй таркалып җитми.* А. Фаткуллин.

ПРОТЕИН *и. биол.* Хайван организмнарында һәм үсемлекләрдә аерым күзәнәкләрнең нигезе булган гади аксым.

ПРОТЕ'КТОР *и. махс.* Тыгыз һава тутырылган шин покрышкасының гадәттә сырлы, калын, нык тышкы катламы, тышчасы.

ПРОТЕКТОРАТ *и.* Көчлерәк капиталистик дәүләткә көчсезрәк дәүләтләрне үзенә буйсындырырга мөмкинлек бирә торган бәйлелек формаларының берсе. *Англия протектораты.* □ *Англия империалистлары, Ямәнгә протекторат көчләп тагу юлында күп кенә уңышсыз омтылышларыннан соң, турыдан-туры сугыш хәрәкәтләре башла*[*ган булганнар*]. Каз. утл.

ПРОТЕКТОРАТЛЫК *и.* Көчле капиталистик дәүләт көчсезрәк капиталистик дәүләтне үзенә буйсындырып тору (бәйлелек формасы). || Шундый бәйлелектә торган ил. *Оман протекторатлыгы.*

Протекторатлык итү — нинди дә булса илне шундый бәйлелектә тоту.

ПРОТЕКЦИОНИЗМ *и. экон.* Капиталистик илләрдә: үз иле промышленностен һәм авыл хуҗалыгын үстерү, аларны чит ил конкурентларыннан саклау максаты белән, чит илләрдән кертелә торган товарларга зур таможня пошлиналары салу политикасы.

ПРОТЕ'КЦИЯ *и.* Зур урындагы, сүзе үтә торган кешенең кемнең дә булса эшенә булышуы, ярдәме, аны яклавы. *Протекция ясау.* □ *Аны шәһәргә мулла итәргә уйлыйлар. Ләкин аңың өчен протекция кирәк була.* М. Гали. — [*Аңа*], *ихтимал, Пинегинның протекциясе ярдәм булгандыр.* Г. Газиз.

ПРОТЕСТ *и.* **1.** Бирәр нәрсәгә катгый рәвештә каршы төшү, ризасызлык белдерү. — *Үзем һәм иптәшләрем исеменнән Нәгыйм абзыйга монда күрәләтә йөзен чытмыйча оятсыз рәвештә ялган сөйләве өчен каты протест һәм нәфрәт белдерәм.* Ш. Камал. [*Володя:*] *„Әгәр безнең шартларны кабул итмәсәләр, протест йөзеннән, без университетны ташлап чыгачакбыз,"— ди.* Р. Ишморат.

2. Бирәр карарга рәсми ризасызлык белдерү. *Прокурор протесты.*

3. *махс.* Вексель белән алынган бурыч тиешле срогында түләнмәү турында рәсми раслау. *Вексельне протестка бирү.* □ *Кырык мең сумлык вексель протестка керергә тора.* Г. Ибраһимов. *Срогында түләмәсәң, вексельнең протест дигән бәлагә әләгүе бар.* Ш. Мөхәммәдев.

4. *махс.* Диңгез пароходы (теплоходы) капитанының суднода авария булу яки йөкнең бозылуы турында рәсми белдерүе. *Дүртенче трюмга тәшү белән, аягым юешлеккә батты. --- Протест язмыйча булмас. Күпме юешләнде икән, буйдан-буйга әйләнеп чыгыйм әле.* М. Юныс.

Протест итү (кылу) *иск.* — 1) ризасызлык белдерү, протест (1 мәгъ.) белдерү. *Протест итеп безнең завод өч көн эшләмәде.* Г. Ибраһимов; 2) *махс.* вексельгә протест (3 мәгъ.) ясау. *Әхмәров вексельләренең артына да нотариус печате басылып, протест кылынды.* Ш. Мөхәммәдев.

ПРОТЕСТАНТ *и.* Протестантлык тарафдары. *Фон Леерс протестант диненең кануннарын шактый вакыт төгәл саклап килде.* Ш. Мөдәррис.

ПРОТЕСТАНТЛЫК *и.* XVI гасырдагы реформация чорында католиклыкка протест йөзеннән барлыкка килгән төрле дини тәгълиматларның гомуми исеме.

ПРОТЕСТЧЫ *и. кит.* Протест белдерүче, ризасызлык белдерүче. [*Горький*] *күп каһарманнарын иске черек тормышларына каршы протестчы итеп һәм бераз идеаллаштырып күрсәтә.* Г. Нигъмәти. *Тукай тормыш хаксызлыкларына каршы рәхимсез протестчы, азатлык һәм тигезлек талап итеп көрәшкә чыгучыларның ялкынлы теләктәше иде.* Х. Хисмәтуллин.

ПРОТИВОГАЗ *и.* Агулаучы матдәләрдән, газлардан, төтеннән һ. б. саклану өчен фильтрлы битлек. *„Газ!" командасы булу белән, противогазыма ябыштым. Күз ачып йомганчы киеп тә куйдым.* М. Әмир. || *с. мәгъ.* Шундый битлекне саклау өчен хезмәт итә торган. *Бер солдат противогаз сумкасыннан бер кисәк икмәк чыгарды.* Н. Дәүли.

ПРОТОДЬЯ'КОН *и.* Зур чинлы дьякон.

ПРОТОИЕРЕЙ *и.* Зур чинлы иерей (рухани). *Затлы ефәктән тегелгән ряса кигән протоиерей - - - чиркәүгә үтеп бара.* Р. Ишморат. *Протоиерей Миловидовның дин тәгълиматы турындагы лекциясе Володяның күңелен генә кайтарды.* Г. Әпсәләмов.

ПРОТОКО'Л *и.* 1. *к.* беркетмә. *Протоколга мәҗлестәге членнар бар да кул куеп, тамгаларын салдылар.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *махс.* Дәүләтләр арасында язма килешү.

◇ **Протокол теле белән әйткәндә** — рәсми, коры тонда язу, сөйләү турында. — *Һуһаять, отчёт-сайлау җыелышы да, протокол теле белән әйткәндә, зур оешканлык белән, эшлекле шартларда үтте.* М. Хәсәнов.

ПРОТОН *и. физ.* Матдәнең атом төше составына керә торган уңай корылмалы элементар кисәкчек. *Протон, позитрон, фотон һәм башка күп элементар кисәкчекләр турында да - - - шуны үк әйтергә мөмкин.* М. Абдрахманов.

ПРОТОПЛА'ЗМА *и. биол.* Хайван һәм үсемлек күзәнәкләрендә бара торган тормыш процессларының нигезе булган ярым сыек матдә.

ПРОТОТИП *и. кит.* Беренче үрнәк, оригинал. || *әд.* Авторга әдәби образ тудыруда оригинал булып хезмәт иткән, тормышта булган кеше. *Повестьтагы геройларның прототиплары бармы? Алар кемнәр?* Э. Касыймов. — *Образның прототибын — авылдашым Гыйльметдинне мин кимендә 30 ел беләмдер.* Р. Мостафин.

ПРОТУБЕРА'НЕЦ *и. астр.* Кояш дискысының кырыена ыргылып чыга торган якты кызган газлар.

ПРОФ- Кушма сүзләрдә „профессиональ союз" мәгънәсендәге беренче кисәк; мәсәлән: **профком, профорг, профбилет, профактив.**

ПРОФАН *с.* Бәрәр өлкәдә мәгълүматы булмаган, надан. — *Килен сайлау эшендә мин үземне бик профан кешедер дип уйлыйм.* Ф. Хөсни. || *и. мәгъ.* Шундый кеше. — *Сез профан түгел, иптәш Мамайкин. Сез тормышта безнең бөтенебезгә караганда да тәҗрибәлерәк, эрудицияле кеше... Сезнең белмәгән нәрсәгез юк.* Ә. Фәйзи.

ПРОФАНЛЫК *и.* Профан булу. — *Кунактан сорап тору килешәме соң? - - - Минем бу профанлыгымны, зинһар, үз алдымда үк гаепләмәгез.* Ф. Хөсни.

ПРОФАШИ'СТИК *с.* Фашизмны яклый торган, фашизм интересларын күзәтә торган. *Профашистик оешма. Профашистик партия.*

ПРОФБЮРО *и.* Профсоюз оешмасының бюросы.

ПРОФГРУ'ППА *и.* Предприятиенең, учреждениенең, уку йортының башлангыч профсоюз оешмасына керә торган группа.

ПРОФГРУППОРГ *и.* Профсоюз группасының сайланып куелган җитәкчесе. — *Соломон Израилевич укыту методикасы эшләрен алып бара, ә Шәфика Сабировна — профгруппорг.* А. Расих.

ПРОФЕССИОНАЛ *и.* Нинди дә булса бер эшне үзенең төп профессиясе, һөнәре итеп алган кеше. *Музыканың кайбер гомум һәм милли төрләрендә профессионаллар белән үзешчәннәр осталыгы арасында аерма юк дәрәҗәдә аз.* Р. Фәхретдинов.

ПРОФЕССИОНАЛИЗМ *и.* 1. Профессиональ осталык; бәрәр нәрсәнең профессиональ сыйфаты. *Югары профессионализмга каршы төшкән кеше — ул артта калган карашларны чагылдыручы.* Н. Жиһанов.

2. *лингв.* Бәрәр профессия кешеләре теленә хас сүз яки тәгъбир (мәсәлән, врачлар телендәге медицина атамалары һәм латинча сүз тезмәләре).

ПРОФЕССИОНАЛЛАШУ *ф.* Профессионаллар рәтенә күчү.

ПРОФЕССИОНАЛЬ *с.* 1. Профессиягә бәйле, профессия сәбәпче булган. *Профессиональ авырулар.* ▭ [*М. Гафуриның*] *аз гына булса да завод, фабрика эше йогынтысына бирелмичә, - - - эшчеләрнең профессиональ теле — атамалар теле белән үз телен баетмыйча яшәве мөмкин түгел.* Г. Нигъмәти. *Әхмәт, профессиональ гадәте буенча, кесәсеннән блокнот белән авторучка чыгарды.* Г. Минский.

2. Профессионал булган. *Профессиональ көрәшче. Профессиональ художник.* ▭ *Яков Свердлов, әле егерменче яшендә генә булса да, җитлеккән профессиональ революционер иде.* А. Расих. *Шамилский, һәвәскәрлек дәверен кичермичә, турыдан-туры профессиональ артист булып китә.* Ә. Еники. || Профессионалга хас. *Профессиональ белем.* ▭ [*Солдатлар*] *үз эшләрен профессиональ осталык белән башкаралар.* С. Баттал. *Милли колоритны бозмыйча, татар моңын тулысынча саклаган хәлдә, профессиональ башкару техникасы үзен акладымы?* Ялкын.

Профессиональ союз — халык хуҗалыгының бәрәр тармагында эшләүчеләрне, бер профессия кешеләрен берләштерә һәм аларның интересларын яклый торган ирекле массакүләм оешма.

ПРОФЕССИОНАЛЬЛЕК *и.* Билгеле бер эшне үз профессиясе итеп алу; профессионал булу. *З. Яруллин белән Солтан Габәшиләр күтәрә башлаган профессиональлек байрагын татар халкының таланлы улы Салих Сәйдәшев тотып алды.* Каз. утл. [*Театр төзелү*] *артистларда профессиональлек хисләрен көчәйтте.* К. Тинчурин.

ПРОФЕ'ССИЯ *и.* Билгеле бер хәзерлек, белем талап итә һәм яшәү, көн итү чарасы булып санала торган эшчәнлек, хезмәт, эш төре. *Профессия алмаштыру. Профессия сайлау. Тракторчы профессиясе.* ▭ *Хезмәт сөйгән кеше һәр профессияне үзләштерә ала. Ә артист профессиясе — чын мәгънәсендә иҗат профессиясе бит.* Х. Сәлимҗанов. *Дөньяда педагог профессиясеннән дә әйбәт эш бармы икән?.* Г. Минский.

ПРОФЕ'ССОР *и.* Югары уку йортларында эшләүче югары квалификацияле укытучыларга яки фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә берничә фәннәр кандидаты тәрбияләгән фәнни хезмәткәрләргә (фәннәр докторла-

рына) бирелә торган гыйльми исем; шул исемгә ия булган кеше. — *Бер авыруның хәле начарланган, профессор операция ясарга булган.* Т. Гыйззәт. *Татар композиторларын укыту һәм тәрбияләүгә күп көч куйган консерватория профессорларының һәм белгечләренең хезмәтләре зур.* М. Җәлил.

ПРОФЕ'ССОРЛЫК *и.* Профессор булу, профессор вазифасы; профессор урынын алып тору. *Яковкин фәнгә бернинди дә катнашы булмаган кешеләрне профессорлыкка кабул итә башлый.* Җ. Тәрҗеманов. — *Бүгеннән үк мине профессорлык вазифасыннан азат итүегезне үтенәм.* Р. Ишморат.

ПРОФЕССУ'РА *и.* 1. Профессор исеме яки урыны. 2. *җый.* Профессорлар. *Бәйрәм студентлар каршында абруй казанган алдынгы профессурага солидарлык, реакцион өлешенә каршы протест күрсәтү төсендә үтә башлый.* И. Рәмиев. *Студиядә әдәби җитәкче булып эшләве аркасында, [Җәлил] Кызыл профессура институтына кереп уку теләгеннән кире кайтырга мәҗбүр булды.* Г. Кашшаф.

ПРОФИЛА'КТИК *с.* Профилактика өчен билгеләнгән, профилактика максаты белән үткәрелә торган. *Профилактик ремонт.* □ *Ул үз китабында төрле авырулардан саклану юлында нинди профилактик чаралар куллану кирәклеге турында файдалы киңәшләр бирде.* И. Рәмиев. — *Инде ялгышам икән, бер профилактик чара булыр, һәрхәлдә, зыян итмәс.* Г. Гобәй.

ПРОФИЛА'КТИКА *и.* 1. *мед.* Авыруны булдырмау өчен алдан күрелгән чаралар. — *Профилактика дигән нәрсә дә бар бит әле. Ашказаның, аннан бавыр-бөерләрне санаторийда бераз тазартып җибәртсәң, начармыни?* Э. Касыймов. *Шәймәрдән куштан: „Докторлар дару белән кеше үтерәләр", — дип, профилактика уздыруга каршы килә.* М. Мәһдиев.

2. *тех.* Берәр нәрсәне (машиналарны, аппаратларны һ. б.) вакытыннан элек тузудан, ватылудан саклау чаралары.

3. *күч. сөйл.* Берәр нәрсәне булдырмау өчен кисәтү чаралары. *Мусаны профилактика тәртибендә генә кулга алырга уйлаганнар иде. Әйтик, мондый операция вакытында гаепләре ачык күренеп тормаган башкаларны да алган шикелле.* Ш. Маннур.

ПРОФИЛАКТО'РИЙ *и.* 1. Профилактика, дәвалау-сәламәтләндерү учреждениесе. *Төнге профилакторий.* 2. Яңа туган бозаулар, бәрәннәр өчен бина яки бүлмә. — *Бозау, тугач та, 10—12 көн шушы профилакторий дип аталган бүлектә тора. Монда коры һәм җылы булырга тиеш.* А. Расих.

3. Профилактик-техник ремонт өчен бина. *Машиналы профилакторийга кертеп, эстакадага бастырдылар.* М. Маликова.

ПРО'ФИЛЬ *и. кит.* 1. Кеше йөзенең яки предметның яннан күренеше.

2. *махс.* Берәр җирнең, предметның вертикаль киселеше. *Җир кабыгының профиле. Күпер профиле.* □ — *Юлның профиленә бик нык игътибар итәргә туры килә, юл узган урында профиль никадәр тигез булса, чокыр-чакыр никадәр кимрәк булса, юлның озынлыгы да шулкадәр кими төшә.* Г. Ахунов. *Барлык катлаулар бергә туфракның профилен тәшкил итәләр.* А. Фаткуллин.

3. *тех.* Прокатның аркылы киселеш формасы. *Төрле профильдә булган корыч.*

4. Хуҗалыкның, нинди дә булса белгечлекнең, оешманың асылын, эш юнәлешен билгели торган төп сыйфатлар җыелмасы. *Институт профиле.* □ [*„Казмаш"*] *профиле еш үзгәреп торган урта кул бер завод иде.* Г. Әпсәләмов. *Сәнгать эшләре идарәсе Татар дәүләт опера театрының профилен билгеләгәндә аны башлыча милли репертуарга корылган милли театр итеп таныган.* М. Җәлил.

ПРОФКОМ *и.* Җирле профсоюз оешмасы комитеты. [*Гәрәйшин*] *вузда чакта ук профком председателе булган.* Г. Ахунов.

ПРОФМӘКТӘП *и.* Профессиональ белем бирә торган махсус уку йорты. [*Исламгәрәй*] *берәр профмәктәпкә китеп, нинди дә булса һөнәргә ия булырга да бик омтылып караган.* Р. Төхфәтуллин.

ПРОФОРГ *и.* Профсоюз оештыручысы (профгруппаның сайлап куелган җитәкчесе).

ПРОФОЕШМА *и.* Профессиональ союзның җирле оешмасы.

ПРОФСОЮЗ *и.* Профессиональ союз. *Профсоюз оешмасы. Профсоюз җыелышы. Профсоюз члены.* □ *Үткән җәй аенда профсоюзлар якшәмбе көн саен субботниклар ясап йөрделәр.* Ш. Камал. — *Твардовский именнесендә ялланып эшләүчеләрнең профсоюзын оештырырга барган идем.* Т. Гыйззәт.

ПРОФТЕХМӘКТӘП *и.* Профессиональ-техник мәктәп.

ПРОХОДЧЫ *и. махс.* Җир астында тау токымнарын казучы, тоннель салучы эшче. [*Галиев*] *Мәскәү метросында проходчы була, аннары Донбасста шахта проходчысы.* Ш. Маннур.

ПРОЦЕДУ'РА *и. кит.* 1. Берәр эш башкаруның алдан билгеләп куелган эзлекле тәртибе. *Сайлау процедурасы. Килешүгә кул кую процедурасы.* □ [*Апаның*] *илле ике яше хөрмәтенә бер-икене күтәргәч (әлбәттә, бу процедурага оялчан кыз катнашмады), --- мәҗлеснең музыкаль бүлеген башларга дигән фикергә килделәр.* Ш. Хөсәенов.

2. *мед.* Врач билгеләгән дәвалау чарасы (ванна, массаж һ. б.). *Врачлар да бик әйбәт, ләкин төрле процедуралар белән җанга тиялләр: су белән, электр, кояш белән, аннары һава, ләм белән дәвалыйлар.* А. Тимергалин. || *с. мәгъ.* Дәвалау өчен билгеләнгән, дәвалый торган. *Ул еш кына коридорга чыга, --- сәгате җиткәч, процедура бүлмәсенә кереп дарулана иде.* Э. Касыймов.

ПРОЦЕ'НТ *и.* 1. Бер бөтен, бер берәмлек итеп алынган санның йөздән бер өлеше (ул % билгесе белән белдерелә). *Процентлар белән исәплэп чыгарy.* □ *Эш үлчәнә процент белән, Ә процентның зуры йөз генә.* Ф. Кәрим. || Бер берәмлек итеп алынган нәрсәнең йөздән бер өлешкә кадәр үлчәнә торган микъдары. — *Сез бу декададагы планны йөз егерме дүрт процентка үтәдегез.* Һ. Такташ. — *Эшләп чыгару нормасы азында илле-алтмыш процентка үсәргә тиеш.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. Капиталның һәр йөз сумына (долларына, маркасына һ. б.) алына торган килер, керем.

3. Ссудага, бурычка бирелгән акчадан файдаланган өчен шул ссуда яки бурыч биреп торучыга түләнә торган акча. *Процентка акча бирү. Процент бирә торган кәгазьләр.* □ *Шушы егерме биш сумны ике ел бирми йөрткән өчен, процент унбиш сум.* Ш. Камал. *Аның әле әүвәлге бурычы йөз тәңкәгә якын булып, ул аның процентын да түләп җитмәгән иде.* Г. Ибраһимов.

4. Эшләгән эш яки килернең күпме булуына карап түләнә торган хезмәт хакы. *Процентка печән чабу.*

ПРОЦЕНТЛАУ *ф.* Процент (1 мәгъ.) чыгару, процент белән исәпләү. — *Процентлап карагач, алар алда килеп чыга.* Г. Галиев.

ПРОЦЕНТЛЫ *с.* 1. Процентлар (1 мәгъ.) белән белдерелгән, билгеләнгән. *Алтмыш процентлы эремә. Кырык процентлы руда. Процентлы чагыштырма.*

2. Процент (2 мәгъ.), доход китерә торган. *Өч процентлы дәүләт заемы.*

ПРОЦЕ'СС *и.* **1.** Берәр эш-хәлнең, күренешнең эзлекле рәвештә алмашып торуы, үсеш барышы. *Үсемлекләрдә матдә алмашу процессы. Дөнья культурасының үсеш процессы.* ☐ *„Кызыл йолдыз" пьесасы --- Советлар илендә авыл хуҗалыгы төзү процессын гәүдәләндерә.* М. Җәлил. *— Сезнең эш процессыгызга без катнашмыйбыз!* Ш. Хөсәенов. ‖ Билгеле бер нәтиҗәгә ирешүне күздә тоткан эзлекле эш-хәрәкәт. *Производство процессы. Технологик процесс.* ☐ *— Мондагы завод цехлары технология процессы ягыннан бер-берсенә бик нык бәйләнгәннәр.* Ш. Камал. ‖ Көчәя барган авыру халәте. *Ялкынсыну процессы.*

2. *махс.* Суд эшләрен карау, тикшерү тәртибе. *Гражданлык эшләре процессы.* ‖ Куелган тәртип буенча суд эшләрен алып бару. *Процесс шулай барганда, --- Шәләнге белән Акташ крестьяннарыннан, татар полыгыннан килгән вәкилләр: „Безне хөкемгә кертегез!" —* [*диләр*]. Г. Ибраһимов.

ПРОЦЕ'ССИЯ *и.* Гадәттә бик күп кешеләр катнашкан тантаналы йөреш, барыш. *Процессия хәзерге Ирек мәйданында туктала.* Х. Сәлимҗанов. *Кайдадыр еракта хәрби процессия трубаларда уйнап үтә.* Ж. Фәйзи.

ПРОЦЕССУА́ЛЬ *с. махс.* Процесска (2 мәгъ.) бәйле. *Процессуаль сроклар. Процессуаль хокуклар.* ☐ *Процесс барлык процессуаль нормаларны нык саклап алып барыла.* Соц. Тат.

ПРОШЕ'НИЕ *и. иск.* Берәр оешма яки власть иясе исеменә язма үтенеч, гариза. [*Камил*] *Петербургка прошение җибәрде.* И. Нуруллин.

ПРР *аваз ияр. к.* пыр. *Син очып йөргәнче, кошчык, прр да прр, Ташла иске тормышыңны, бездә тор.* Г. Тукай.

ПРС(С) *ы.* Мәчене куганда әйтелә. [*Ул:*] *„Прс-с-с!" — дип кычкырып җибәрде һәм җирдән йодрык кадәр зурлыкта таш алып, аны песигә таба ыргытты.* Г. Галиев.

ПРУЖИ'НА *и.* **1.** Берәр механизмның, җайланманың күбесенчә спираль рәвешендә бөтерелгән (бөгелгән) сыгылмалы корыч тасмадан яки корыч чыбыктан гыйбарәт бер кисәге. *Сәгать пружинасы.* ☐ *Өметбаев, сөенеп, авыртканы кулы белән дә пружинаны этә башлады.* Г. Гобәй. *— Мин аңар бит американский пружина куйдым. Гаҗәп сәгать бит бу.* Г. Газиз.

2. *диал.* **пружина́.** Бишек асып тирбәтә торган бормалы тимер чыбык.

3. *күч.* Берәр предмет, күренеш, эш-хәлнең юнәлеш бирүче көче, сәбәбе. *Заводның үз эчендә вакыйгаларны хәрәкәткә китерә торган пружина табылмаган.* Каз. утл.

◇ **Пружина кебек (шикелле)** — бик тиз, капыл (торып китү, йөрү турында). [*Закирга*] *берәр эш кушсаң, пружина кебек сикереп тора иде.* И. Гази. [*Алар*], *яткан җирләреннән пружина шикелле атылып торып, солдатларның өсләренә акырдылар.* А. Шамов. **Пружинасы ычкыну** *гади с., шелт.* — түземлелеге бетеп, үз өстеннән контроль югалту, артык кызып китү; акылына зәгыйфьлек килү. *— Анаңның теленә шайтан төкергән аның. Пружинасы бер ычкынса, җыеп та ала алмый ул аны.* А. Шамов. *Кешеләрнең күзләре үзгәргән, сөйләшләрендә пружиналар ычкынып-ычкынып киткән төсле китек һәм сөйкемсез тавышлар ишетелә иде.* Ш. Камал. **Пружинасын бору** *сөйл.* — бик нык кисәтеп кую. *— Айрат әзерләп бетергән иде инде җыелышны, нишләптер сүрелде әле. Мохтаров пружинасын борган ахры аның.* Г. Ахунов.

ПРУЖИ'НАЛАНУ *ф.* Пружина кебек бөгелү, бөтерелү һәм язылу; пружина рәвешен алу. *Бабай белән әби бауның --- пружиналанып торуы беткәнче, һәр бөртеген сыдырып чыгалар.* Г. Гобәй.

ПРУЖИ'НАЛЫ *с.* Пружинасы булган, пружина куелган. *Пружиналы матрац. Пружиналы үлчәү.* ☐ *Сәкинә елады-елады да пружиналы караватына бөгәрләнеп ятты.* Ю. Әминев. *— Элек заманда да байларда бик әйбәт пружиналы тарантаслар буладыр иде.* Ш. Камал.

ПРУСС *и.* **1.** Балтик диңгезенең көньяк яр буенда, түбән Висла һәм Неман елгалары янында яшәгән һәм күпчелеге XIII гасырда Тевтон ордены тарафыннан юк ителгән, ә бераз немецлаштырылган балтик кабиләләре төркеме. *Прусс теле.* ‖ *с. мәгъ.* Чыгышы белән Пруссиянеке булган, Пруссиядә туып-үскән.

2. *с. мәгъ.* Пруссаклыкка хас, пруссаклык белән сугарылган. [*Аның*] *күңеленда прусс солдафоны утыруын онытмаска кирәк.* Каз. утл. *Бу* [*үҗәтләнү*] *борын-борыннан яшәп килгән прусс муштрасының --- нәтиҗәсе иде.* Г. Сафиуллин.

ПРУССАК *и.* Элекке Пруссия дәүләтендә яисә Пруссия җирендә туып-үскән яки шунда яшәүче немец. *Немец шәһәрләрендәге йортлар --- тупас пруссак казармаларын хәтерләтәләр.* Г. Иделле. *Икесенең дә уенда бөек полководец Суворовның: „Руслар пруссакларны һәрвакыт тукмадылар", — дигән сүзләре саклана.* Х. Мөҗәй.

ПРУССАКЛЫК *и.* Элеккеге Пруссия дәүләтендә һәм Германия империясендә хакимлек иткән реакцион, милитаристик, бюрократик режим.

ПРХ *аваз ияр. к.* пырх. *Бөтен строй прх итеп көлеп җибәрде.* М. Әмир. *Әтәч „прх! прх!" итеп ханның баш түбәсенә кунды.* Г. Тукай.

ПРЮНЕ́ЛЬ *и.* Аяк киемнәренең өске өлешенә, мебель тышлауга китә торган юка, тыгыз киҗе-мамык, ефәк яки йон тукыма. ‖ *с. мәгъ.* Шундый материалдан тегелгән. *Прюнель ботинкалар.*

ПРӘННЕК *и.* Балга, бәрәңге балына яки шикәр сиробына катырылган һәм төрле аш тәмләткечләр салып пешерелгән баллы вак күмәч. *Прәннек пешерү цехы.* ☐ *Ул миңа кызыл билле прәннекләр, чуклы конфетлар алып килде.* Ф. Хөсни. [*Газизә апа*] *кибеттән бармак шикелле озынча прәннек --- алып кайтты.* Ә. Фәйзи.

ПРӘННЕКЛӘНҮ *ф. сөйл. шелт.* Кылану, кәнфитләнү, иркәләнү.

ПРӘННЕКЧЕ *и.* Прәннек пешерүче яки прәннек сатучы.

ПРӘШКӘ *и.* Ремень яки бил каешын беркетеп куя торган каптырма.

Прәшкә аты — *к.* мичәү аты. *Аңа һәрвакыт прәшкә аты җигәргә кирәк булган.* Г. Газиз. **Прәшкәгә җигү** — *к.* мичәүгә җигү. *Җизнинең күк айгырын төпкә, Госманнарның кара туры алашаларын прәшкәгә җигеп, пар ат белән киттек тә бардык.* Ф. Хөсни.

ПСАЛТЫРЬ *и.* Христиан динендә: гыйбадәт вакытында көйләп укыла торган догалар җыентыгы; библиянең бер өлеше.

ПСЕВДОКЛАССИЦИЗМ *и.* XVII гасырдан алып XIX гасырның башына кадәрге чор әдәбияты һәм сәнгатендә антик үрнәкләргә ияруне һәм ныклы эстетик кануннар системасына буйсынуны күтәреп чыккан юнәлеш. *Бу иске әдәбият тарих истилахында псевдоклассицизм дип атала.* Г. Ибраһимов. ‖ Архитектурада: шул ук чорда антик һәм яңарыш чоры архитектурасы традицияләрен эзлекле рәвештә үстергән төп стильләрнең берсе. *Псевдоклассицизм алымнары белән ясалган биналар модага керә.* Б. Урманче.

ПСЕВДОНИ'М *и.* Язучы, артист, художник һәм башка кайбер кешеләрнең үзенә үзе алган уйдырма исеме яки фамилиясе. [*Тукайның*] *яратып кулланган псевдонимы да бит татар фольклорының усал, кытыклап үтерә ала торган рәхимсез, капризлы, мифологик „Шүрәле"дән гыйбарәт.* Г. Нигъмәти. *Заһидә Бурнашева, --- үз фамилиясен яшереп, „Гыйффәт туташ" псевдонимы белән шигырьләр бастыра башлый.* М. Гайнуллин.

ПСЕВДОНИМЛАШТЫРУ *ф.* Псевдоним итү, псевдонимга әйләндерү. *Кулъязмадан шагыйрьнең исемен һәм нисбәсен таба алмагач, Г. Сәгъди һәр хикмәттә кабатланган традицион „мәүля колый" гыйбарәсен алып, шуны псевдонимлаштырган булса кирәк.* Ф. Фасеев.

ПСЕВДОНОМА'СТИКА *и.* Филологиянең һәр төрле псевдонимнарны ачу һәм өйрәнү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Псевдономастика — татар филологиясендә әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән фән.* М. Мәһдиев.

ПСИХ *и. гади с.* Үз-үзен тота алмый торган, нервлы кеше. — *Псих ул! Бөтен дөнья дошман аңа, беркемне танымый, танырга да теләми.* Э. Касыймов. — *Сугыштан куркам, йөрәгемә ярамый, псих мин.* Н. Дәүли.

ПСИХАСТЕ'НИК *с. мед.* Психастениягә бәйле, асылы психастения булган. *Психастеник авырулар.* || *и. мәгъ. сөйл.* Психастения белән авыручы кеше.

ПСИХАСТЕНИ'Я *и. мед.* Бик нык кыюсызлык, куркаклык, һәрнәрсәдән шикләнү һәм бәйләнчек уйлар уйлаудан гыйбарәт нерв авыруы. *Психастения билгеләре.* □ *Мондый очракларда балаларда кыюсызлык, куркаклык, шикләнү тамыр җәя башлый, һәм алар психастения, шикләнү неврозы белән тиз авыручан булып китәләр.* Соц. Тат.

ПСИХИАТР *и.* Психиатрия буенча белгеч — врач. — *Баланың нервлары какшаган, — дип бүлдерде аны психиатр.* А. Тимергалин.

ПСИХИАТРИК *с.* Психик авыруларны дәвалый торган. *Бу дача психиатрик больница янәшәсендә урнашкан.* И. Рәмиев.

ПСИХИАТРИ'Я *и.* Психик авыруларны һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнә торган фән. *Д* [*ул*] *үзе, әнисенә сиздермичә, психиатрия китабын караштырырга кереште. Шунда ул әтисенең сәер тоелган сүзләрен, баш әйләндергеч хәрәкәтләрен акылдан шашу симптомнары итеп аңлады.* Г. Кутуй.

ПСИ'ХИК *с.* Психикага бәйле. *Психик процесслар. Психик үзенчәлекләр.*

Психик авыру — ми үзәкләре зарарланган, нерв системасы какшаган кеше. [*Минһаж*], *психик авыру сыман кыланып, атлаган саен аксап, аксаган саен тешен ыржайтып, авызын чалышайтып түргә узды.* С. Баттал. **Психик авырулар** — ми үзәкләре зарарланудан, үзәк нерв системасы какшаудан туган авыру төрләре. **Психик атака** — оборонада торучыларны куркыту, аларның психикасын, ихтыярын җимерүгә исәпләнгән атака. *Немецлар дүртенче мәртәбә психик атакага ташланалар.* Ф. Булатов.

ПСИ'ХИКА *и.* Тере организмнарның югары нерв эшчәнлегенә нигезләнгән аерым бер үзлеге (ул чынбарлыкны үз аңында яки нервларында чагылдыра алуда, тойгыларда, кичерешләрдә, ихтыярда һәм фикерләү үзенчәлекләрендә сизелә); рухи халәт. || Шул үзлекнең кемдә дә булса конкрет чагылышы. — *Хәтер һәм, гомумән, кеше психикасы — бик нечкә* [*нәрсә*]. А. Тимергалин. *Аның нервлары бик какшаган булса да, психикасында зыян барлыгын тапмадылар.* Ш. Маннур.

ПСИХО- Кушма сүзләрдә „психикага бәйле" мәгънәсендәге беренче кисәк; мәсәлән: **психопатология, психоневрологик, психотерапевтик** һ. б. ш.

ПСИХОАНА'ЛИЗ *и.* Хәзерге заман буржуаз психологиядә һәм психопатологиядә кешенең рухи тормышын психикадагы „аңсыз" нәрсәнең „аңлылык" өстеннән хакимлеге белән аңлата һәм җенси теләккә хәлиткеч әһәмият бирә торган идеалистик юнәлеш.

ПСИХОАНАЛИ'ТИК *с.* Психоанализга нигезләнгән, асылы психоанализ булган. *Психоаналитик тикшеренү.* □ [*Идрис*] *психоаналитик анализлар ясап, кешенең үз эчәк-бавырларыннан чыгып кына киң дөньяга бәя биреп йөрүчеләрне яратм*[*ый*]. А. Гыйләҗев.

ПСИХОЗ *и.* **1.** Баш мие зарарланудан туган авыру халәт. || *сөйл.* Кеше психикасында сәерлек, нормадан тайпылыш.

2. Берәр вакыйганың, идеянең, күренешнең һ. б. ш. кешеләрдә курку, ышаныч югалту, бәйләнчек фикерләр һ. б. тудырудан гыйбарәт көчле рухи тәэсире. *Кайбер илләрдә сугыш психозын көчәйтергә теләүче аерым кешеләр табыла.* Сов. әд.

ПСИХО'ЛОГ *и.* **1.** Психология белгече. — *Ул тарихчы да, биолог та, психолог та.* А. Тимергалин.

2. Икенче бер кеше психологиясенең бөтен нечкәлекләрен сизә, белә торган кеше. *Моңарчы аңа төбәлеп, аның йөзендәге һәрбер үзгәрешне күзәтеп утырган һәм оста психолог саналган доктор Унгляубе, чынлап та, әле генә Мусаның башыннан узган шул сәер уйларны куәтләгән шикелле, юаткыч сүзләр белән аңлатырга тотынды.* Ш. Маннур. *Яшь кенә булуына карамастан, нинди оста психолог бу Нәсимә! Ничек ансат тотты бит каракны.* М. Мәһдиев.

ПСИХОЛОГИЗМ *и.* **1.** Философиянең нигезе итеп субъектив психологияне санаган идеалистик юнәлеш.

2. Кешеләрнең рухи кичерешләрен, психологиясен тирәнтен сурәтләргә, нечкәләп анализларга һәвәслек. *Халитовта урынсыз психологизмга тартымлык бар.* М. Җәлил. [*М. Гафуриның*] *Октябрьгача язылган хикәяләрендәге психологизм үзенең социаль яктылыгы ягыннан артык тирән түгел.* Н. Юзиев.

ПСИХОЛО'ГИК *с.* **1.** Психологиягә бәйле, психологиягә мөнәсәбәтле. *Гомуми психологик закон. Психологик бәхәсләр.*

2. Кешенең рухи халәтенә, психикасына бәйле. — *Безнең эш, туган, акча исәпләренә генә түгел, психологик факторларга да корылган...* Г. Ахунов. *Җавапның көтелгән вакыттан шактый күп кичегеп килүе аңарда көрәшкә хәзерләнгән вакыттагыга охшашлы психологик киренкелек тудырды.* Ш. Камал. || Кеше психологиясен белүгә нигезләнгән, кешенең эчке дөньясын ача, күрсәтә торган. *Психологик уен.* □ *Закирны соңгы актта психологик яктан бай, җанлы образ итеп, бөтен тулылыгы белән күрсәтергә кирәк.* М. Җәлил.

3. Персонажларның психологиясен тирәнтен сурәтләүгә корылган. *Психологик драма.* □ *Көчле психологик романнар язучы Фёдор Достоевскийга гашыйк булуым өчен дә мин Фатих абыйга бурычлы.* Х. Сәлимҗанов. *Җәлаш, иҗтимагый бер тип булудан бигрәк, психологик характер итеп бирелә.* Г. Нигъмәти.

ПСИХОЛОГИСТ *и.* Психологизм (1 мәгъ.) тарафдары. *Кайбер психологистларның, монда аерым шәхес рухы түгел, бәлки милли рух, коллектив психологиясе аңланырга тиеш, дип караулары мәсьәләне төзәтә алмый.* Г. Алпаров. *Психологистлар телне рух эшчәнлеге дип таныйлар.* Ш. Рамазанов.

ПСИХОЛОГИСТЛЫК *и. к.* психологизм (1 мәгъ.). *Ул тел гыйлемендә субъектив идеалистлык, психологистлык карашларын урнаштыра.* Г. Алпаров.

ПСИХОЛО'ГИЯ *и.* 1. Психик, рухи эшчәнлекнең закончалыкларын, үсешен, формаларын өйрәнә торган фән. *Гомуми психология. Психология тармаклары. Психология кабинеты.* □ [*Мәскүрә*] *психологиядән дә бишкә генә укый иде, хәтта аңа шул фән буенча аспирантурада калырга тәкъдим иттеләр.* С. Сөләймановa.

2. Билгеле бер эшчәнлекнең шартлары булып тора торган психик процесслар җыелмасы. *Хезмәт психологиясе. Сугыш психологиясе.* □ *Тикшерүчелек психологиясенең гадәтенчә, ишек алды, ак мичтән түргәчә сузылып-күтәрелеп куелган киндер чаршау --- аның күзеннән кичтеләр.* Г. Ибраһимов. *Иске горефгадәтләр, буыннар буенча тәрбияләнеп килгән крестьян психологиясе әледән-әле аның чабуыннан артка сөйрәп тора.* Г. Әпсәләмов.

3. Психика, характер үзенчәлекләре, рухи халәт. *Ул кешеләрнең психологиясен яхшы белә, аңлый иде.* А. Шамов. — *Аны дулкынландырырга ярамый. Авыруның психологиясен мин беләм бит инде.* С. Шәкүров.

ПСИХОНЕВРОЛО'ГИЯ *и.* Медицинаның психик һәм нерв авыруларын өйрәнү һәм дәвалау белән шөгыльләнә торган бүлеге. || *с. мәгъ.* Шул авыруларны өйрәнү һәм дәвалау белән шөгыльләнә торган. — *М. Вахитов психоневрология институтында укый.* Р. Нафигов.

ПСИХОПАТ *и. сөйл. хур.* Психик авыру (кеше турында); псих. — *Психопат, сүз тегермәне Керенскийның да тәмен татыдык.* К. Тинчурин. *Театр әдәбиятыбызны Смирнов шикелле бер кара вә ахмак психопатның зәһәрле карашы аркылы уздырырга мәҗбүр булган* [*идек*]. Ф. Әмирхан.

ПСИХОПА'ТИЯ *и.* Рухи яктан какшау, психик нормаль булмау.

ПСИХОПАТО'ЛОГ *и.* Психопатология белгече.

ПСИХОПАТОЛО'ГИК *с.* Психопатологиягә бәйле, асылы психопатология булган. *Психопатологик тикшеренү.*

ПСИХОПАТОЛО'ГИЯ *и.* Психик авырулар турында гомуми тәгълимат. *Үзенең беренче хезмәтендә үк Павлов --- эксперименталь психопатологияне яңабаштан корырга теләге булу турында язды.* Сов. әд.

ПСИХОТЕРАПЕВТ *и.* Психотерапия буенча белгеч.

ПСИХОТЕРАПИ'Я *и.* Кеше психикасына тәэсир итеп дәвалау методы (мәсәлән, гипноз). *Дару-фәләннең файдасы булмас аңар, карт абзыкайга, пенсионер кешегә, хәзерге заманча әйтсәк, аңа психотерапия кирәк. Бары шул.* А. Гыйләҗев. [*Камил*] *психотерапия буенча фәнни тикшеренүләр алып бара.* С. Сөләйманова.

ПСИХОТЕ'ХНИК *с.* Психотехникага бәйле, психотехникага нигезләнгән. *Психотехник метод.*

ПСИХОТЕ'ХНИКА *и.* Практик психологиядә кешенең берәр эшкә, профессиягә яраклы булу-булмавын билгеләү методларын өйрәнә торган бүлек.

ПСИХОФИ'ЗИК *с.* Психофизикага бәйле, асылы психофизика булган. *Психофизик эксперимент.*

ПСИХОФИ'ЗИКА *и.* Эксперименталь психологиядә тынычсызландыру дәрәҗәсе һәм аны сизү көче арасындагы үзара мөнәсәбәтне тикшерә торган бүлек.

ПСИХОФИЗИОЛО'ГИК *с.* Психофизиологиягә бәйле, асылы психофизиология булган. *Психофизиологик законнар.* □ *Һинд-Европа тел гыйлеме телне --- психофизиологик күренеш дип изах итә.* Г. Алпаров.

ПСИХОФИЗИОЛО'ГИЯ *и.* Психологиянең психик күренешләр һәм алар нигезендә яткан физиологик процесслар арасындагы мөнәсәбәтне өйрәнә торган бүлеге.

ПСИХРО'МЕТР *и.* Һаваның дымлылыгын үлчи торган прибор.

ПТР *и.* Танкка каршы ата торган махсус мылтык. [*Безнең*] *өч-дүрт автомат, бер птр, бер кул пулеметы бар.* Х. Камалов.

ПТУ *и.* Профессиональ-техник училище.

ПУ *аваз ияр.* Мылтык атканда тоник кына чыга торган тавышны белдерә. *Минһаҗ малайның борынына бармагы белән баса да, аткан тавыш чыгарып: „Пу!" — дип кычкыра.* С. Баттал.

ПУАНСОН *и. тех.* Металлны кысып эшкәртү өчен штампның кабарынкы өске кисәге. — *Син дә бит әле кичә генә бер пуансонны тимерчелектә яндырдың. Оныттыңмыни?* А. Расих.

ПУ'БЛИКА *җыйд. и.* Театрга, кинотеатрга, циркка һ. б. ш. урыннарга спектакль, фильм һ. б. карар өчен җыелган тамашачылар. *Сафия ролен уйнаучы ханым, бик әкрен вә тотлыгып сөйләп, --- мөмкин кадәр публикага арты илән торырга азаплануы илә ул кадәр яхшы түгел иде.* Г. Тукай. — *Минем бик күптәннән публика алдында җырлаганым юк.* Ш. Камал. || *сөйл.* Җыелган халык, кешеләр. *Вагон эчендәге публиканың үзара мөнәсәбәте яхшы ук үзгәргәне күренә.* Г. Гали. || Вакытларын бергә уздыра торган кешеләр төркеме; җәмәгать. *Бездә яхшы гына зур грамота*[*лы*] *публика бар, аларга милли хикәя, милли роман, милли шигырь, милли театр кирәк...* Ж. Вәлиди. *Уфада кымыз бер генә җирдә. Публика* [*шунда ук*] *эчеп бетерә.* Г. Тукай.

ПУБЛИКА'ЦИЯ *и.* Газета-журналларда, китапларда басылган, дөньяга чыгарылган хезмәт. *Фәнни публикация.* □ *„Совет Татарстаны" газетасында безнең „Мулланур Вахитов мәкаләләре" дигән публикация-без бар.* Р. Нафигов. || Берәр нәрсә турында басма игълан. — *Биктимер абзый, публикация китердем. --- Мирхәйдәр абый үлгән. --- Менә полыгыннан язу җибәргәннәр.* Т. Гыйззәт.

ПУБЛИЦИСТ *и.* Иҗтимагый-политик темаларга язучы кеше. *Бу язучылар* [*З. Бигиев, М. Акъегетзадә*], *художник булудан бигрәк, публицистлар. Болар өчен әдәби әсәр аша үз сыйнфый карашларын тулырак, үтемлерәк итеп бирү беренче бурыч булып тора.* Г. Нигъмәти. — *Язучы көн сорауларына кирәкле нәрсәләрне вакытында яза белә дигән сүзләрне күп укыгансыз, әлбәттә. Публицистны шуннан башка гомумән күз алдына китереп булмый.* Г. Әпсәләмов.

ПУБЛИЦИ'СТИК *с.* Публицистикага мөнәсәбәтле, публицистикага хас. *Публицистик эшчәнлек. Публицистик жанр.* || Хәзерге көн өчен әһәмиятле иҗтимагый-политик мәсьәләләргә кагыла торган. *Публицистик поэзия — ул поэзиянең иң сугышчан төрө.* Ә. Исхак. [*Г. Камалның*] *„Азат", „Азат халык", „Дхбар", „Казан мөхбире", „Әльислах" һәм „Йолдыз" газеталарында басылган тәнкыйть, публицистик мәкаләләре* [*бар*]. М. Гали.

ПУБЛИЦИ'СТИКА *и.* 1. Хәзерге көн өчен әһәмиятле темаларга багышланган иҗтимагый-политик әдәбият—әдәби жанр. *Публицистика теле.* □ *Гариф Гобәйнең „Коръән серләре" — татар прозасы өчен бөтенләй яңа булган әдәби публицистика жанрында язылган әсәр.* М. Әмир. || Иҗтимагый-политик әдәбиятның башка жанрдагы әсәрләрдә кулланыла, очрый торган үзенчәлекле сыйфатлары, элементлары. *Язучы күп урында Бикташовны җанлы хәрәкәттә, бәйләнештә, җанлы сурәт итеп художество чараларын белән ачу урынына, турыдан-туры публицистикага бирелеп, аның идеяләрен сөйләп китә.* М. Җәлил.

2. *җыйд., әд.* Шул жанр әсәрләре.

ПУГАЧ *и.* Уенчык пистолет. *Ул берсеннән-берсе матур уенчыклар, --- колакларны тондырып ата торган гайрәтле пугачлар* [*күрде*]. А. Расих.

ПУ'ДЕЛЬ *и.* Озын бөдрә йонлы бүлмә эте.

ПУ'ДИНГ *и.* Боткага яки эремчеккә җимеш, шикәр, йомырка, май һ. б. кушып кыздырып пешерелгән ашамлык. [*Студент*] *пудингын актаргалап карады да чәнечкесен өстәлгә ташлады.* М. Юныс.

ПУ'ДРА *и.* Биткә, муенга яга торган гаять вак һәм йомшак (күбесенчә хуш исле) порошок; кершән. *Пудра сибү. Пудра савыты. Пудра сөртү.* □ — [*Асрау*] *минем Гафифәнең пудраларын алып ягынган, бөтенләй менә, бигайнидә, бер ком гарәбенең битен акбурга буяган төсле булган.* Г. Камал.

ПУ'ДРАЛАУ *ф.* Пудра ягу, пудра сөртү; кершән ягу. *Сәгыйдәнең дә артык тырышып пудраланган* (т ө ш. ю н.) *йөзе сөйкемсез булып тоела башлады.* Г. Ахунов.

ПУК-ПУК *аваз изр.* Мылтыктан атканда чыккан тавышны белдерә. || *хәб. функ.* Атуны белдерә.— *Якын киләсе булма,* [*юкса*] *пук-пук үзеңне!* Ш. Маннур.

ПУЛ I *и. иск.* Акча, тәнкә. *Аныесы уңай, кесәм тулы пул да булса.* М. Укмасый.

ПУЛ II *и.* Капиталистик монополияләрнең бер формасы (бу очракта барлык табыш бер кассага керә һәм үзара алдан билгеләп куелган пропорцияләрдә бүленә).

ПУЛАТ *и.* (Гадәттә таштан салынган) зур өй; сарай II (1 мәгъ.). *Өчәр-дүртәр катлы зур таш пулатлар* [*салынган*]. Г. Коләхметов. — *Мин кайчан да булса бер пулатта торачакмын.* К. Тинчурин.

ПУЛЕМЁТ *и.* 1. Пуляларны бик тиз ата торган автомат корал. *Кул пулемёты. Станоклы пулемёт. Зенит пулемёты. Эре калибрлы пулемёт. Пулемёт лентасы. Пулемёт көпшәсе. Пулемёт ноктасы.* □ *Идел аркылы болынга ата торган безнең пулемётларның пуляларының авыл өстеннән сызгырып очалар.* И. Гази. *Пулемётны хәзерләргә һәм, урам чатыннан чыгарып, көпшәсен минем аяклар арасыннан колоннага төзәргә куштым.* Х. Мөҗәй.

2. *с. мәгъ.* Шул корал белән коралланган. *Пулемёт ротасы.* □ *Пулемёт командасы начальнигы Тәрҗеманов аларның хәрәкәтен бинокль белән карап торды.* Ш. Усманов. || Шул корал өчен махсус эшләнгән, махсус әзерләнгән. — *Башта без әнә тегендә пулемёт оялары казыдык.* И. Гази.

ПУЛЕМЁТЧЫ *и.* Пулемёттан атучы кеше. *Тачанкадагы пулемётчы ике аягы өзелгәннән соң да сугыштан китмәгән.* Г. Әпсәләмов. *Пулемётчының патроны беткәнен дошман да сизеп алды.* А. Әхмәт.

ПУЛЕМЁТЧЫЛЫК *и.* Пулемётчы булу, пулемётчы хезмәте. *Пехота командиры Храбрый Костиннан аны үзенә пулемётчылыкка сорап йөри.* Г. Гобәй.

ПУЛО'ВЕР *и.* Гәүдәгә сыланып тора торган, якасыз һәм каптырмасыз трикотаж фуфайка. *Ялан тәнгә кигән юка йон пуловер кызның калку күкрәгенә, бил нечкәлегеннән аска таба салмак кына киңәеп киткән янбашларына сыланып, гәүдә сылулыгын сиздереп тора.* М. Юныс.

ПУЛТ *аваз изр. к.* пылт. [*Сәгыйть*] *сал астыннан пулт итеп килеп чыккан.* М. Шабаев.

ПУЛУН *и. бор.* Әсирлек. *Николай икенченең дворецтан чыгарга ирлеге җитми, ул халык кулында пленда (пулунда).* РСДРП прокламациясе.

Пулун төшү — дошман кулына әсирлеккә төшү. *Ул җәмәгатьләрдин --- бәгъзысы пулун төшеп һәм авырып, сырхап кайткан.* Каз. утл.

ПУЛЬВЕРИЗА'ТОР *и.* Сыекчаны тузан хәленә китереп бөркү, сиптерү өчен кулланыла торган прибор.

ПУ'ЛЬМАН *и.* Зур пассажир һәм товар вагоннарының махсус төре. *Бөгелмәгә* [*цемент*] *зур пульман вагоннарында кайтарыла.* М. Хәсәнов. *Бу зур пульман вагоны идә. Авыр ишеген шылдырап ачтык.* Ә. Еники.

ПУ'ЛЬПА *и.* 1. *мед.* Тешнең эчендәге йомшак матдә (аңа нервлар урнашкан була); теш йомшагы.

2. *махс.* Җир һәм тау эшләрен көчле басым астындагы су белән юдырып башкарганда барлыкка килгән тау токымы яки балчык белән су кушылмасы.

3. *тех.* Металлны аерып алу өчен су яки башка эреткеч салып сыеклатылган вак руда.

ПУЛЬПИТ *и. мед.* Теш йомшагы ялкынсыну.

ПУЛЬС *и.* 1. Йөрәк кысылып кан этәргәндә, кан тамырлары стенасының өзек-өзек тирбәнеше; тамыр тибеше. [*Римма*] *Алексейның --- беләзегеннән тамырын табып, пульсын санады.* Х. Камалов. || Кан тамырларын капшап караганда шул тирбәнешләр сизелә торган урын. [*Врач*], *Бибиҗамал апаның пульсын тотып, йөрәген тыңлап карады.* Ш. Хөсәенов.

2. *күч.* Тормышның, берәр эшчәнлекнең, машина эшләвенең һ. б. ритмы, темпы. *Иҗтимагый тормыш пульсы. Двигатель пульсы.*

ПУЛЬСАР *и.* Космостан даими рәвештә бер көчле, бер көчсез радио импульслары җибәрүче нейтрон йолдыз. — *Пульсарлар, квазарлар кешелек дөньясы алдына конкрет проблемалар куйды.* А. Гыйләҗев.

ПУЛЬСА'ТОР *и. тех.* Даими рәвештә өзек-өзек хәрәкәтләр ясап торучы механизм; ток өзгәләгеч. *Пневматик пульсатор. Электронлы пульсатор.*

ПУЛЬСА'ЦИЯ *и.* 1. (Йөрәкнең, артериянең) кабатланулы тибеше; (канның) ритмлы хәрәкәте; пульс тибеше, тамыр тибеше.

2. *махс.* Берәр нәрсәнең (мәсәлән, күләмнең, форманың, тизлекнең, басымның) өзлексез кабатланулы үзгәреше. *Югары ешлыктагы пульсация.*

ПУЛЬСА'ЦИЯЛЕ: пульсацияле ток *физ.* — зурлыгы периодик рәвештә үзгәрсә дә, юнәлеше бер якка гына булган ток.

ПУЛЬТ *и.* 1. Музыка коралында уйнаганда ноталар кую өчен озын терәккә беркетелгән авыш тактадан гыйбарәт җайланма. *Дирижёр пульт артына менеп басты. --- Оркестрда кереш музыка башланды.* Ш. Хөсәенов.

2. *тех.* Берәр нәрсәне эшләтү, берәр нәрсә белән идарә итү приборлары куелган урын (өстәл, стенд һ. б.). *Электр станциясе пульты. Диспетчер пульты.* □ *Инструментны күтәрткән чакта, инерция аркасында, торба идарә пульты ягына, ягъни бораулаучы ягына таба авыша.* Г. Ахунов.— *Нәрсә бу? — Шартлату пульты. Менә бу рубильникны басасың да, тауның асты өскә килә!* Н. Дәүли.

ПУ'ЛЯ *и.* Кул коралыннан яки пулемёттан ату өчен гильзаның өске өлешенә урнаштырылган очлы кургаш кисәге. *Яндыргыч пуля. Шартлагыч пуля. Пуля ярасы. Очраклы пуля.* □ *Якты рткыч пулялар, фейерверкка охшап, баш очыннан сызгырып оча башладылар.* Ә. Айдар. *Пуля Тукташевның беләген яралады.* Х. Камалов.

◇ **Пуля кебек** — бик тиз (эш-хәрәкәт темпына карата).

ПУ'МА *и.* Зур гәүдәле ерткыч кыргый мәче (Америкада яши).

ПУМАЛА *и.* 1. Көлне, корымны себерү, идән юу һ. б. ш. эшләр өчен бер очына мунчала яки чүпрәк бәйләнгән озын таяк. [*Без пинкәдән*] *фабрик-завод идәннәрен юа торган пумала да ясыйбыз.* Г. Гобәй. — *Кисмәгең сусыз тора. Пумалаңның мунчаласы юк.* Т. Гыйззәт.

2. Нәрсәне дә булса буяу өчен гадәттә кыска таяк очына утыртылган кыл бәйләме. *Буяу пумаласы. Дегет пумаласы.* □ *Зифа бүген дә агачлар белән*

маташа, озын саплы пумала белән зәгыйфь кәүсәләрне акка буйый иде. А. Гыйләҗев.

3. *күч. гади с. кимс. к.* пумала баш. — *Җитәр, пумала, әйт дим мин сиңа, кем тирес түкте?* М. Әмир.

◇ **Пумала баш** *гади с. кимс.* — 1) тузгыган чәчле хатын-кыз турында. — [*Башка киленнәр*], *синең теге пумала башың кебек, атлаган саен тәртәгә тибеп тормыйлар.* А. Шамов. — *Телеңне тый, пумала баш!* Ф. Бурнаш; 2) гомумән хатын-кыз турында кимсетеп әйтелә.

ПУМАЛАЛАНУ *ф.* Пумала кебек булу, тузгу. [*Курчакның*] *борыны озын, сары чәче пумалаланып, җилләнеп тора.* М. Җәлил.

ПУНКТ *и.* **1.** Җир өстендә, Җир шарында билгеле бер урын. *Картага иелеп, связной әйткән пунктларны карыйм.* И. Гази. ‖ Кеше яши торган урын (авыл, шәһәр һ. б.). *Торак пункт.* □ — *Юкса, мин ничә шәһәр, ничә пункт алганыбызны каян хәтерләп бетерер идем?* А. Шамов. *Ерак пунктлардан иген ташу, йөк йөртү атка йөкләнә.* М. Гафури.

2. Берәр эш-шөгыль өчен махсус җаһазландырылган өй, бүлмә һ. б. ш. *Диспетчерлык пункты. Кабул итү пункты. Медицина пункты. Сөйләшү пункты. Күзәтү пункты. Эвакуация пункты.* □ [*Аның*] *атасы ашлык хәзерләү пунктында механик булып эшли.* Г. Кутуй. *Команда пунктын әле яңа гына сугыш үткән бер подвалга урнаштырам.* И. Гази.

3. Рәсми документта яки берәр тексттa цифр яки хәреф белән билгеләнгән аерым статья, бүлек, параграф. *Анкетаның бишенче пункты.* □ *Без договорга тагы бер пункт өстәргә булдык.* Г. Гобәй. *Оешма уставының дүртенче пунктында: „Оешма үзенең членнарын һәртөрле юллар белән химая итүне өстенә ала", — диелгән.* Ш. Камал. ‖ Докладта, чыгышта, бәхәстә аерым фикер, мәсьәлә. — *Бу пунктта мин Вагыйзов иптәш белән тулысынча кушылам.* К. Тинчурин. — *Зөһрә туташ, бу пунктта мин сезнең якта инде.* Ф. Әмирхан.

4. *махс.* Хәрефләрне һәм буш калган урыннарны исәпләү берәмлеге (ул 0,4 *мм* га тигез).

ПУНКТИР *и.* Нокталар яки сызыкчалардан гыйбарәт өзек-өзек сызык. *Пунктир сызу.* ‖ *с. мәгъ.* Нокталар яки сызыкчалардан гыйбарәт өзек-өзек. *Пунктир сызык.*

ПУНКТИРЛАУ *ф.* Пунктир сызу, пунктир төшерү.

ПУ'НКТЛАП *рәв.* Рәттән, тәртип белән; җентекләп. *Тукайның тәнкыйть турындагы бер мәкаләсеннән фикерләрне чүпләп алып, шуларны тәртипкә салып, пунктлап бирү — яхшы факт.* Н. Исәнбәт. [*Алар*] *бу* [*кагыйдәләр*] *дә мәктәпләр өчен төзелгән икәнен пунктлап исбат итәләр икән.* Ф. Әмирхан.

ПУНКТУАЛЬ *с.* Берәр эшне җиренә җиткереп үтәүчән, бик төгәл. *Ләлә Зариповнаны бит бик пунктуаль, артык таләпчән кеше дип әйтәләр.* Л. Ихсанова. [*Г. Ибраһимов*] *бик пунктуаль иде. Соңга калып килгәнен яки, дәресен вакытында тәмамлый алмыйча, звоноктан соңга калып, тәнәфес вакытын кысканын хәтерләмим.* Г. Ибраһимов тур. ист.

ПУНКТУАЛЬЛЕК *и.* Пунктуаль булу.

ПУНКТУА!ЦИЯ *и. лингв.* Тыныш билгеләрен кую системасы. *Пунктуация хаталары. Пунктуация кагыйдәләре.* □ *Пунктуация мәсьәләсендә бездә әле ачыкланып бетмәгән һәм нормалашып җитмәгән урыннар күп.* Ш. Рамазанов.

ПУ'НКЦИЯ *и. мед.* Авыруны билгеләү яки дәвалау максатыннан чыгып, кан тамырларын яки төннең башка урыннарын кадап тишү. *Пункция ясап, хлорлы кальций белән стрептомицин катнашмасы җибәрелде.* Э. Мөэминова.

ПУНСОН *и. махс.* Матрица ясау өчен бер ягы кабарынкы хәрефтән яки башка билгеләрдән гыйбарәт дүрткырлы тимер кисәге, калып. *Сенат типографиясендәге гарәп хәрефе белән коелган матрицалар һәм пунсоннар Казанга күчерелә.* И. Рәмиев. *Хәрефләрне кою өчен калып—пунсон эшләнә.* Ә. Кәримуллин.

ПУНШ *и.* Кызыл аракыга, коньякка су, шикәр, лимон согы яки берәр төрле җимеш суы кушып ясалган спиртлы эчемлек.

ПУПАЛАУ *ф. гади с.* Сөйләү, сөйләшү. [*Ихсанов*], *ярты-йорты пупалап, листовканың эчтәлеген түрәсенә әйтеп бирде.* Ш. Маннур.

ПУПЫНУ *ф. гади с.* Сөйләшү, сөйләү. *Таня инде татарча ярыйсы гына пупына. Шулай да Тимержан әйткәнне тулысынча аңлап җитмәде.* Н. Фәттах.

ПУРГЕН *и.* Эч йомшарткыч дару.

ПУРИЗМ *и. к.* пуристлык. [*Буржуаз яшьләр*] *арасында милли телне иске сафлыгына кайтарырга омтылу (пуризм) бик нык таралган.* Г. Алпаров. *Халыкка аңлаешсыз кайбер гарәп-фарсы алынмаларыннан арыну --- процессының буржуаз милләтчелек һәм пуризм белән бернинди дә бәйләнеше юк.* Ш. Рамазанов.

ПУРИСТ *и.* Пуризм тарафдары. *Пантюркистларның төрекчелеген кире каккан шикелле, пуристларның саф төркичелеккә кире кайтырга маташуларына да Тукай айнык карый алды.* Г. Халит.

ПУРИ!СТИК *с.* Асылы пуристлык булган, пуристлык белән сугарылган. *Буржуаз милләтчеләр кара реакция елларында пуристик алым куллану юлына басалар.* Л. Җәләй.

ПУРИСТЛЫК *и.* Телне барлык алынма сүзләрдән чистартуга омтылыш; телне һәртөрле неологизмнардан, стилистик кытыршылыклардан арындыру өчен көрәш.

ПУРИТАН *и.* **1.** XVI—XVII йөз Англия буржуазиясе арасында феодализмга каршы юнәлдерелгән һәм башта англикан чиркәвен католиклыктан арчуны максат итеп куйган дини-политик агым тарафдары.

2. Гадәттән тыш әдәпле, әхлаклы тормыш алып бару тарафдары. ‖ *с. мәгъ.* Гадәттән тыш әдәплелекне, ныклы әхлакны алга куйган. [*Г. Ильяси*] *кызларга менә нинди пуритан тәрбиясе бирергә кирәш итә.* Г. Рәхим.

ПУРИТАНЛЫК *и.* Пуританның үз-үзен тотышы, пуритан карашлары. *Намуслылык пуританлык түгел.* С. Фәйзуллин. [*Сергей*] *гыйффәтле кеше, --- әмма пуританлыгы белән ир-ат даирәсенә комачауламый иде.* С. Баттал.

ПУРКИ *и. сөйл. хурл.* **1.** Чакырылмаган җиргә, ашка, мәҗлескә сәдака алыр өчен йөрүче, соранырга яратучы кеше; соры корт (гадәттә, шәкертләр турында). *Пурки! Пурки! Нәрсәгә мәсҗеттә син тыңкышланып Сайрыйсың, коръән ватасың, тук сыер күк мышнанып, Җомгадан соң кемдә аш барны сизә ак тешләрең? Соң теге көнге хәмелдән күп [„төшемме"] эшләдең?* Г. Тукай. — *Иң элек, мин Петербургка пурки булып ашка йөрергә кирәкмәдем.* К. Бәкер.

2. Һәрнәрсәгә тыкшынучы, оятсыз, әрсез кеше.

ПУРКИЛАНУ *ф. сөйл. хурл.* Пуркилык итү.

ПУРКИЛЫК *и. сөйл. хурл.* Лаеклы булмаса да, берәр эшкә әрсезләнеп, комсызланып керешү; оятсызланып хәер эстәү.

ПУРЫЙ *и. диал. әвф.* Куянның бала хайваннар янында әйтелә торган исеме; куян.

ПУСТ *и. бор.* Тире савыт, тире кап. *Ышанма син дустыңа, инә тыгар пустыңа.* Мәкаль.

ПУСТАУ *и. к.* постау. *Кызыл пустау җәелгән өстәл янында кара киемле бер кеше күренде.* И. Гази. *Бу катта пустау суга торган, агачтан ясалган кул станнары бер-бер артлы тезелеп киткән.* М. Гали.

ПУТА *и. диал.* **1.** Гадәттә озынча тукыма кисәгеннән гыйбарәт билбау; кушак. *Кызыл пута. Ефәк пута.* □ *Корбангали абзый инде өстенә чикмәнен киеп, билен пута белән буып өлгергән.* Ф. Хөсни. *Тун өстеннән кызыл пута бәйләгән --- тәбәнәк бер кеше* [*күренә*]. М. Галәү.

2. Түбә тактасының түбәнге башы белән кәрниз арасына кадаклана торган юка агач.

ПУТАЛ *и. махс.* Бакыр һәм цинк эретмәсеннән гыйбарәт ялган алтын. *Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының алтын путаллар белән бизәлгән зур заллары чагылып үтте.* Р. Ишморатова. ‖ Шул эретмәдән гыйбарәт буяу. *Батыргали агайны, исемен алтын путал илә язып, кыйммәтле рамкаларга куярга* [*кирәк*]. Ш. Мөхәммәдев. ‖ *с. мәгъ.* Шул эретмәдән ясалган, шуңа буялган. *Түшәмнәрдә, уңа алмый торган кыйммәтле путал каймалар белән уратылып, художествоны табигать күренешләре сурәтләнә.* Ш. Камал. *Кыз аз гына өрсәң дә очып китәргә торган путал кәгазьне бүрек эченә куя.* М. Максуд.

ПУТАЛЛАУ *ф.* Путал белән каплау, путал белән буяу. *Хәзер аның бу яңа кибетенең ишекләре өстендә эре хәрефләр белән путаллап язылган.* М. Гафури.

ПУТАЛЛЫ *с.* Путал белән капланган, путал йөгертелгән. *Төсе киткән путаллы такта* [*эленгән*]. Ш. Камал. *Ал медале аның путаллы, Куандырды анай карчыгын.* М. Җәлил. ‖ Кырыйлары путал белән бизәлгән. [*Кыз*] *почмакта торган зур гына путаллы көзге каршысына килде.* Г. Ахунов. *Кара сакаллы берәү үзенең чапан бөркәнгән хатыны белән зур-зур путаллы тәлинкәләр сайлый.* Ә. Фәйзи.

ПУТЁВКА *и.* **1.** Берәр урынга (мәсәлән, ял йортына, санаторийга, уку йортына яки эшкә) баручыга бирелә торган таныклык. *Май аенда театр миңа путёвка биреп, ял йортына Ялтага җибәрде.* Х. Сәлимҗанов. *Минем путёвкам Усть-Омга өязенә язылганлыктан, Валунскига барып җиткәч, губернаның мәгариф бүлегенә кереп тормадым.* Э. Касыймов.

2. *махс.* Транспорт йөртүчеләрдә маршрутны һәм үтәлә торган эшне күрсәтә торган кәгазь. *Көн кичкә авышкач, идарәгә шофёр Зиннәт килеп керде: „Путёвка яз әле! — диде ул табельче Энҗегә. — Комлы ярга борчак илтеп кайтырга кирәк“.* М. Маликова. [*Хәйруш үзбушаткычта*] *эшләргә ризалыгын белдерде, путёвкалар яздырды.* М. Хәсәнов.

3. *күч.* „Әдәбият“, „тормыш“ һ. б. ш. сүзләрдән соң килгәндә: берәр нәрсәгә, эшкә юл, мөмкинлек, юнәлеш бирә торган нәрсә. *„Әльислах“ аңа зур журналистикага һәм зур әдәбиятка путёвка бирә.* Сов. әд.

ПУТЕМАР *и. диал. этн.* Өч-дүрт рәт тәңкә тезеп ясалган һәм бер иңбашыннан икенче култык астына киелә торган укалы киң тасма; хәситә. | *с. мәгъ. Яшел сондык өсләрендә Путемар бөтүемне тышлыймын.* Җыр.

ПУТЧ *и.* Бер төркем заговорчыларның дәүләт перевороты ясарга авантюристик омтылышы; шундый дәүләт перевороты. *Будапештта фашистлар путч оештыра.* Г. Сафиуллин.

ПУФ *аваз ияр.* Авыр итеп сулаганда, авыздан күп итеп һава чыгарганда яки эш күплектән уфтанганда, көрсенгәндә чыккан калын тавышны белдерә. — *Пуф! Болар кайда югалдылар инде тагын?* Г. Камал. —*Пуф... ух... Җибәр!* М. Фәйзи. ‖ Күп итеп пар, төтен чыкканда булган тавышны белдерә. — *Пуф, пуф. Гыжт, гыжт... — дбәү! — малайлар чырылдашып, кычкырышып* [*паровоздан*] *читкә качтылар.* Безнең юл.

Пуф итү — 1) шундый тавыш чыгару. *Ат пуф итеп бер сулап ала.* К. Тинчурин. [*Хәлим*] *берьюлы ярты карбызны ашап, корсагы таш булып каткач, пуф итеп бүрәнәләр өстенә барып утырды.* И. Гази; 2) кабару, күперү. [*Хәйдәр*] *пуф итеп тора торган, менә дигән зур кара мыеклы.* Ә. Фәйзи; 3) тәкәбберләнү, үзен әллә кемгә кую. [*Байлар*] *озын-озын тоннарын тектерәләр төлкедән, Пуф итеп йөргәннәрен күрсәң, чыдый алмассың көлкедән.* Ш. Мөхәммәдев.

ПУФ-ПУФ *аваз ияр.* Авыр итеп сулаганда чыккан өзек-өзек калын тавышны белдерә. ‖ *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Юан корсаклы, калын җилкәле мещаннар бик эре бүкәннәр булып, пуф-пуф тын алып утыралар.* Г. Ибраһимов.

Пуф-пуф итү (килү) — 1) өзек-өзек һәм озак-озак сулыш чыгару. *Көндез эшләп, кичен минем белән булышып ул да шактый талчыккан булгандыр инде, биш-ун минут дигәндә пуфф-пуфф итеп йоклап та китте.* В. Нуруллин. *Барый лапаста пуф-пуф килеп күшәп яткан сыер янында берүзе калды.* Ш. Рәкыйпов; 2) авыр сулау; пуфылдау. [*Кадыйр бай*], *кибәк ашап күбенгән сыер кебек, пуфф-пуфф итеп тора.* Г. Ибраһимов. *Батыргали агай илә Шубин да пуф-пуф итеп, ашыга-ашыга пароходка йөгер*[*деләр*]. Ш. Мөхәммәдев; 3) күп итеп пар, төтен яки газ чыгару. *Казан өстенә ябылган түгәрәк агач капкачның әле бер читеннән, әле икенче читеннән пуф-пуф итеп пар бәрә.* М. Шабаев. — *Паровозга авырга туры килә, чак тарта, бичара, пуф-пуф килеп бара.* А. Гыйләҗев, А. Яхин.

ПУФЫЛДАУ *ф.* Пуф-пуф иткән тавыш чыгару. [*Әти*] *озын итеп бер пуфылдап сулады да сөйләнергә тотынды.* Р. Төхфәтуллин. *Пуф-пуф пуфылдап пар чыгаручы казан --- сүлпәнлек, җансызлык тойгысы уята.* М. Шабаев.

ПУХ *аваз ияр.* Мылтык, туп атканда чыга торган капылт, калын тавышны белдерә. — *Ул җибәрә алмый андый ракетаны! Җибәрсә дә аз гына күтәрелә дә, пух!.. Ярыла да кире җиргә әйләнеп төшә!* Г. Бакиров.

◇ **Пух итү** — сулыш алу авырайганчы, күп ашау; тәмам тую. — *Корсак тутырып пух иткәнче ашап чыгасың да эшләп торып җибәрәсең, әй.* Г. Бәширов. [*Кәҗә*] *шулай итеп күчә-күчә, корсагын пух итеп тутырганчы ашап йөри бирә.* Г. Галиев.

ПУХ-ПРАХ: пух-прах килү *сөйл.* — җимерелү, таркалу, юкка чыгу, бозылу (эш, тормыш турында). — *Беттем мин, ди, беттем, авылдашлар, Пух-прах, ди, килде минем эш.* Н. Дәүли.

ПУ'ШКА *и.* **1.** *к.* туп II (1 мәгъ.). *Тиз аткыч ике пушка, туры бәрдереп, бульвардагы юнкерларга ут ачты.* К. Нәҗми. — *Кара әле, улым, безнең совет пушкалары ничә чакрымга аталар?* Т. Гыйззәт.

2. *мед.* Радиоактив нурлар белән дәвалау аппараты.

3. Городки уенында: бишенче таякчыгы дүртпочмак рәвешле тезелгән таякчыклар өстенә куелган фигура. *Уен кызып кына барганда, мин оядагы пушканы бер бәрүдә сугып чыгарыйм әле дип, тәпәчемне бар көчемә ыргыт*[*тым*]. Р. Төхфәтуллин.

◇ **Пушка ите** *кит. хупл.*—басып алу сугышларында көчләп үлемгә җибәрелә торган солдатлар массасы. *Гитлерга Россияне җиңү өчен яңа пушка ите кирәк.* Ә. Исхак. **Пушкага алу** — нәрсә теләгәнне белү яки теләккә ирешү өчен алдау юлы белән эш итү. — *Туктә әле, син нәрсә? Мине пушкага аласың. Андый хыял минем башыма да кергәне юк.* Р. Ишморат.

ПУШНИ'НА *җый. и.* Кыйммәтле мех ясала торган җәнлек тиреләре; мех товар. *Дүрт кеше, компания булып, мех һәм пушнина илә сәүдә кыла.* Ш. Мөхәммәдев. [*Рәҗәпов*] *бездән бер катка түбән, пушнина цехында эшли.* Ә. Еники.

ПУҖУМ *и. диал.* Йорт һәм бәрәнге бакчасы урыны; ихата (2 мәгъ.). — *Җирен миңа бирсен. Иң әйбәт пуҗумда кычыткан үрчетеп ята.* А. Гыйләҗев. — *Безнең иске пуҗум җиде генә сажин иде, шуңа өстәмә итеп ындыр юлы дигән бер киң тыкрыкны безгә бирделәр.* Ш. Маннур.

ПФЕ'ННИГ *и.* Германиядә марканың йөздән бер өлешенә бәрабәр вак акча. *Фрау Якоп кибетендә әйбер унбиш пфенниг торса, күрше кибеттә шул ук әйбер ун пфенниг торыр.* Н. Дәүли.

ПФИ, ПФФИ *ы. сөйл.* Берәр нәрсәгә яки кешегә кимсетеп, аның берни әһәмияте, кыйммәте юк дип караганда әйтелә. — *Пффи! Тапкан гүзәлләр солтаны!* Г. Камал. — *Пфи, сөрсегән ич ул [ит]!* Мәзәк.

ПШЫЙК *ы. сөйл.* Бернәрсә дә булмау, калмау турында әйтелә. — *Пшыйк сиңа эшләпә! Бер атуда ике куян аулыйм дип торганда, пшыйк, берсе дә эләкмәде.* М. Хөсәен.

ПЫВАЙ-ПЫВАЙ *ы.* Бозау чакырганда әйтелә.

ПЫВЫН *и. диал.* Кеше гәүдәсенең оча сөяге белән кабырга арасындагы өлеше; бил.

ПЫЖ *и.* Ау мылтыкларының патроннарында: дары белән ядрә арасына тыгыла торган киез, катыргы, тире кисәге. — [*Патронга*] *дары саласың да пыж тыгасың, аннан менә шуның хәтле ядрә. Аннан янә пыж белән томалап куясың.* Г. Гобәй. ‖ Көпшә авызыннан корылган элекке ау мылтыкларында заряд өстеннән тыгыла торган йомарланган киез, катыргы, тире кисәге.

ПЫ'ЖИК *и.* Төньяк боланының яшь бозау тиресе. ‖ *с. мәгъ.* Шул тиредән тегелгән. *Ишек янында --- пыжик бүрек кигән --- Мәүлиханов басып тора.* Г. Әпсәләмов.

ПЫЖУ *ф. диал. к.* пәҗү. [*Карчык*] *өч кадак пыжыган бәрәнге алыр өчен чират торган.* К. Нәҗми.

ПЫЖЫГУ *ф. диал.* Эсседән әлсерәү, тирләү. *Терлекләр абзарда пыжыгып ята.*

ПЫЖЫК *с. диал.* Үпкәчел, юкка-барга турсаючан (кеше турында).

ПЫЖЫЛДАУ *ф. к.* быжылдау. *Күбәләкләр арасында умарта кортлары белән юллы-юллы сары шөпшәләр, юан-юан төклетуралар да пыжылдап очалар.* Г. Рәхим.

ПЫЖЫТУ *ф. диал.* Берәр нәрсәне яки эшне харап итү; бөлдерү. *Кулы кычыткан — эшне пыжыткан.* Мәкаль.

ПЫЛ *и. бор.* **1.** *к.* пул 1. — *Бакыр йөзеген белән бакыр беләзеген ничә пыл тора?* Ә. Шәмин.

2. Калай алка. *Алты аяк, ике тояк, җилкәсе пыл, уртасы тел, гакыллы аңлар, ахмак тыңлар алтмыш алты ел.* Табышмак.

ПЫЛАУ *и.* Майга салып, тәмләткеч кушып пешерелә торган итле дөгедән гыйбарәт ашамлык. — *Кичәге бүләк багу мәҗлесендә Мәрфуганың пылавы кызарган иде.* Ф. Әмирхан.

ПЫЛАЯК *с. сир.* Ак бәкәлле (ат турында).

ПЫЛДЫР-ПЫЛДЫР *аваз изл.* Кошлар канат какканда, тукыма җилдә җилфердәгәндә һ. б. ш. очракларда чыга торган җиңелчә тавышны белдерә. *Пылдыр-пылдыр төрелә-төрелә тургайлар да Таң шатлыгы көен көйләп менеп бара.* З. Ярмәки. ‖ *с. мәгъ.* Бытыр-бытыр *Ит кунмаган авызга пылдыр-пылдыр сүз бирә, ди; Миңа юк башка бадырайган [күпне күрүчән] сүз бирә, ди.* Мәкаль.

ПЫЛТ *аваз изл.* Сыеклыкка берәр вак нәрсә төшкәндә, тамчы тамганда яки ут капылт сүнгәндә чыккан тавышны белдерә.

Пылт итеп — кайдан да булса капылт кына, йомшак кына итеп (килеп чыгу турында). *Шайтан теге кешенең эченнән сыра бөкесе кебек пылт итеп атылып килеп чыга.* Г. Гобәй. **Пылт итү** — капылт кына, йомшак кына тавыш-аваз чыгару.

ПЫЛТ-ПЫЛТ: пылт-пылт итү (килү) — 1) бер күтәрелү, бер кысылу; бер кабыну, бер сүнәр дәрәҗәгә килү (ут яну турында). *Минем фонарем кыек астында урап йөргән кискен җилдән бер-ике тапкыр гына пылт-пылт итте дә сүнде.* Ә. Еники; 2) кан күп килүдән яки башка сәбәптән сизелерлек булып тибү, калтырану (бит, тән, кан тамырлары һ. б. турында). [*Аның*] *сул як бите пылт-пылт итеп тибә-калтырый, йөрәге авыртыр дәрәҗәгә җитеп сыкрый иде.* М. Әмир.

ПЫР, ПЫР-ПЫР *аваз изл.* Кечерәк кош очып киткәндә, канатларын тиз-тиз какканда, берәр нәрсә әйләнгәндә яки дерелдеп торганда чыккан тавышны белдерә. ‖ *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып; пырылдап (1 мәгъ.). *Шул агачларның арасында Очарсыз пыр да пыр.* М. Гафури. *Шул урындук, гөнаһ шомлыкка, бер чыпчык йөри иде азык эзләп, пыр-пыр очып.* Г. Тукай. ‖ *рәв. мәгъ.* Бик тиз (йөгерү, йөрү турында). *Әйдә, йөгер пыр да пыр!* Н. Исәнбәт.

Пыр итү (килү), пыр-пыр итү (килү) — 1) (очканда, әйләнгәндә) шундый тавыш чыгару, пырылдау (1 мәгъ.). *Кайдадыр якында гына бытбылдык тавышы ишетелә, ә сукмак аша, пыр-пыр итеп, ниндидер кошлар очып уза иде.* Ә. Шәмин. *Пыр килеп бөтен үрдәкләр күтәрелделәр.* Ф. Кәрим; 2) шундый тавыш чыгарып очу, әйләнү. [*Песнәк*] *пырр итте дә тәрәзә төбендәге каенга барып кунды.* Д. Аппакова. *Бер чигенә [кош], Бер килә, Пыр тузына, Пыр килә!* Ш. Галиев; 3) *күч. сөйл.* Ачулану, дулау. *Зөһрә, Шәңгәрәй керүгә, яулыгы белән йөзен каплый да пыр-пыр итеп чыгып китә.* Г. Ибраһимов.

◇ **Пыр туздыру** — 1) тәртипсез рәвештә тарату, чәчү, сибү. *Калтырана, Актарына Сәнди, Пыр туздыра өстәл асларын.* З. Мансур. *Совет гаскәрләре бара Пыр туздырып буранны.* Г. Камал; 2) таркату, җимерү, тар-мар итү, юкка чыгару. *Усал бер тавыш егетнең уйларын пыр туздырып ташлады.* Г. Минский. *Исән булсак, бер кайтырбыз Дошманны пыр туздырып.* Җыр; 3) бик нык ачулану, дулау. — *Фәрхи әби һәммәбезне пыр туздырыр.* Ш. Камал. **Пыр туздырып** — бик нык, бик каты. *Яңа авыл һаман эшли пыр туздырып.* М. Гафури. — [*Бәрәнкәем*], *пыр туздырып акырып, капкага таба ычкынды.* Ф. Кәрим. **Пыр тузу** — 1) бик нык таралу, чәчелү, сибелү, һавага очу. *Завод-фабрикалар бертуктамый үкергән пушкаларның снарядларыннан пыр тузын җимерелеп беттеләр.* А. Алиш; 2) таркалу, җимерелү, юкка чыгу, тар-мар ителү (хуҗалык, байлык, оешкан кешеләр төркеме һ. б. турында). *Әй, „кара көч“, кешелек Дөньясыннан көлмә син! Бервакытта пыр тузарсың, дөлләнерсең көлгә син!..* М. Гафури; 3) бик нык ачулану, дулау, гауга чыгару, котырыну. — *Бәдри мулла абзый каладан кайткан. Мәктәптә пыр туза: „Патша сурәтен алып ташларга кирәк, Николай очкан, аның законы да йөрми хәзер, сурәте дә кирәкми“, — ди.* Х. Кәрим. [*Хуҗа*], *арба рәтләп майланмаса, пыр туза.* М. Гафури. **Пыр тузыну** — *к.* пыр тузу (3 мәгъ.). *Дәү әниләре пыр тузына башлады: „Кәлтә елан да булдымы бүләк! Шул гына җитмәгән иде!“* — [*ди*]. С. Әдһәмова. *Әле бер сәгать алдан гына шушы егет өчен пыр тузынып ачуланган Шәйхулла абзый сүрелеп үк китте.* Каз. утл. **Пыр тузып** — бик нык, бик каты, бик кызу (йөрү, кул чабу). *Без, кызык итеп, пыр тузып кул чаптык.* М. Җәлил. *Атлар пыр тузып чабалар.* Ф. Хөсни. — [*Сиражетдин*] *пыр тузып өй эчендә йөгергәләп йөри.* Г. Камал.

ПЫРАК *и. дини.* Дини тәгълимат буенча: „теге дөньяда" мөселманнарны күккә очырта торган канатлы ат. *Нур тоташты җиргә күктән, иңде нурдан бер пырак.* Г. Тукай. *Атың яхшы булса — бу дөнья-ның пырагы.* Мәкаль.

ПЫРАН-ЗАРАН: пыран-заран килү — 1) төрле якка тузгу, таралу; тәртип бөтенләй бетү (әйберләр турында). *Бүлмә пыран-заран килү;* 2) таркалу, чуалу, болгану. *— Моңарчы тыныч кына яшәгән коллектив, ул килгәч, пыран-заран килеп бетте.* Х. Вахит; 3) тузгу, дулау, гауга кубару. [*Ул кеше*] *сүзенә колак саламы, әллә үз белдегенчә пыран-заран килеп кенә йөриме?* Э. Касыймов; 4) юк-барга тотылу, әрәм-шәрәм булып бетү (мал-мөлкәт турында). **Пыран-заран китерү** — 1) тузгыту, тарату, чәчү. *Бүлмәне пыран-заран китерү;* 2) бөтенләйгә тар-мар итү, юкка чыгару. *— Теге Харьков итчесенең эшләрен Москвада пыран-заран китереп ташлаганыгызны мин бик яхшы хәтерлим.* А. Расих; 3) (мал-мөлкәтне) юк-барга тотып бетерү, сарыф итү, тарату. [*Хәбибулла*] *беренче ирдән калган мал-мөлкәтне пыран-заран китерә башлады.* Ш. Хөсәенов.

ПЫРАНЛАТУ *ф. сөйл.* **1.** Бик каты куу; куркытып качыру. *Бәдри бүлмәдәге балаларны пыранлатып чыгарды.* И. Гази.

2. Бик каты әрләү, ачулану. *Габделгазизнең үзендә дә гаеп булды. Атларын яхшылап кумаган иде. Хәбир бабай бик дөрес пыранлатты аны.* В. Нуруллин.

ПЫРАНЛАУ *ф. сөйл.* Бик каты ачулану, дулау, тавыш куптару. *Бүлмәдән пыранлап чыгып китү.*

ПЫРАХЛАТУ *ф. сөйл.* **1.** Куркытып пырх иткән тавыш чыгарту. [*Ягъфәр*] *әлеге тавыкны пырахлатып куып чыгарды.* М. Зарипов. || Куркытып, пырх иткән тавыш чыгартып куып җибәрү.

2. *күч.* Кемне дә булса ачуланып куып чыгару, куып тарату.

ПЫРАХЛАУ *ф.* Пырх иткән тавыш чыгару.

ПЫРГУ *ф. диал.* **1.** *к.* пыр тузу (1 мәгъ.).

2. Көч белән, зур басым белән су сибү (яки сибелү).

ПЫРГЫ *и. бор.* Зур басым белән су сиптерә торган насос эчәгесе очына киертелгән җиз көпшә; брандспойт. *Янгынчылар күргәннәр, Пыргы тотып килгәннәр, Су сиптергәч пыргыдан, Чыдый алмый ыргыган.* Н. Исәнбәт.

ПЫРГЫТУ *ф. диал.* **1.** Тузан, мамык шикелле нәрсәләрне бик нык туздыру.

2. Көч белән, зур басым белән су сиптерү.

ПЫРДЫМ: пырдымы юк *диал. — к.* пырдымсыз (4 мәгъ.). *Саламның ягарга пырдымы юк.*

ПЫРДЫМЛЫ *с. диал.* **1.** Җайлы, күндәм, басынкы, сабыр. *Пырдымлы хатын.*

2. Эш рәтен белүче, юньле.

3. Бәрәкәтле, күпкә җитүчән.

ПЫРДЫМСЫЗ *с. диал.* **1.** Тиз ачуланучан, тиз кабынучан, сабырсыз, холыксыз, үз-үзен тота белми торган. *Пырдымсыз кеше. Пырдымсыз ат.*

2. Әрсез. *Миңа, яланаяклы пырдымсыз бер малайга, монда искитәрлек берни дә юк иде.* Г. Бәширов.

3. Эшнең рәтен белмәүчән, юньсез, мәнсез. *Пырдымсыз кешеләр.*

4. Бәрәкәтсез. *Йомшак утын пырдымсыз була.* Мәкаль.

ПЫРДЫМСЫЗЛАНУ *ф. диал.* **1.** Тиз ачуланып китү, тиз кабынып китү, сабырсызлану, холыксызлану. *Пырдымсызланыр вакытларда да Луиза басымчаклык күрсәтеп килде.* А. Гыйләҗев. || Чыгымчылау. [*Ат*] *ияргә өйрәнгән икән, пырдымсызланмады, --- салмак кына юырта бирде.* Г. Мөхәммәтшин.

2. Урынлы-урынсыз сүзләр сөйләү, тәкәллефсезләну, тыйнаксызлану.

ПЫРКЫТУ *ф. диал.* Пыр туздыру, куркыту; пырахлату (1 мәгъ.). *Ишек алдындагы тавыкларны пыркыта-пыркыта капка төбенә киләм.* Ш. Маннур.

ПЫРЛАВЫК *с.* Пыр итеп оча, әйләнә торган.

ПЫРЛАТУ *ф. сөйл.* **1.** Пыр иттереп очырту.

2. *күч.* Бик нык ачулану, әрләү, тиргәү.

ПЫРЛАУ *ф.* **1.** Пыр итү, пырылдау (1 мәгъ.). *Ояда-гы кош курыкты, коты очты, Тотмасыннар дип, пырлап читкә очты.* М. Гафури. *Сезнең яланда да бездәге күк Пырлап оча икән тургайлар.* М. Җәлил.

2. *күч. сөйл.* Каты ачулану, дулау. *Мәхдүмә тагы да котырыбрак, ачу илә: „Мин синең илә сөйләшмим!" — дип пырлап, табынга аркасын биреп утыр-[ды].* Ш. Мөхәммәдев. [*Хатын*] *үзенә карата мондый игътибарсызлыкка түзә алмыйча, пырлап: „дй, дөмек инде алайса!" — диде дә икенче бүлмәгә чыгып китте.* А. Расих. || Үзалдына ачуланып, үпкәләп йөрү.

ПЫРНАЛ: пырнал куагы *бот. — к.* очлы яфрак.

ПЫРСЫЛДАУ *ф.* „Пырс" кебегрәк тавыш чыгару. || Шундый тавыш чыгарып ярсу, усаллану. *Мәче, пырсылдап, мич башына очты.* Г. Бәширов.

ПЫРТ, ПЫРТ-ПЫРТ *авазияр.* Әйбер кинәт кенә, бик аз гына ертылганда, мотор эшләп, төтен, газ тоник шартлап чыкканда булган тавышны белдерә. || *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып.

Пырт (пырт-пырт) итү — 1) шундый тавыш чыгару. [*Сәхип*] *кабызу рычагына бер генә типкән иде — мотор шундук кабынып, пырт-пырт-пырт итеп эшли дә башлады.* В. Нуруллин; 2) берәр нәрсә кинәт кенә ертылып китү.

ПЫРТАЮ *ф. диал.* Үпкәләү, турсаю. *— Мин кычкырганга пыртаясы юк.* Т. Миңнуллин.

ПЫРТЛАВЫК *и. диал.* Бер өлеше икенче өлешендәге ояга өлешчә кереп, кием капламаларын яки изүләрен төймәли торган калай сәдәп; *русчасы:* кнопка.

ПЫРТЛАУ *ф. сөйл.* **1.** Пырт итү. || Пырт итеп ертылу.

2. *күч.* Кинәт, көтмәгәндә ачулану, әрләү, тиргәү, дулау.

ПЫРТЛЫЙ *и. диал. к.* пыртлавык. — [*Сандыкта*] *эреле-ваклы сәдәпләр, каптырмалар, пыртлыйлар* [*бар*]. Ш. Маннур.

ПЫРТЫК I *с. һәм и. сөйл. к.* ертык-пыртык. *Ертык пыртыктан көләр.* Әйтем.

ПЫРТЫК II *с. диал.* Үпкәчел, тиз үпкәләүчән (кеше турында).

ПЫРУШТИ *и. диал. этн.* Керәшеннәрдә язын уразa алдыннан беленнәр пешереп, күңел ачып үткәрелә торган мәҗүси бәйрәм.

ПЫР-ФЫР: пыр-фыр килү — пырылдау катыш фырылдау. *Машина пыр-фыр килеп урыныннан кузгалды...* Р. Төхфәтуллин.

ПЫРХ *авазияр.* Көчкә тыелып торганнан соң кинәт көлеп җибәргәндә булган тавышны белдерә. || Кош кинәт очып киткәндә канат кагудан барлыкка килгән яки ат пошкырганда чыккан тавышны белдерә.

Пырх итү — шундый тавыш чыгару. *Яшьләр пырх итеп көлеп җибәрделәр.* М. Хөсәен. *Ат колакларын шомарта, я булмаса, „пыр-р-р-рх-х" итеп пошкырып куя.* Ш. Маннур.

ПЫРХ-ПЫРХ *авазияр.* Көчкә тыелып торганнан соң, авыз һәм борыннардан тавыш чыгарып, өзек-өзек, кинәт-кинәт көлгәндә барлыкка килгән тавышны белдерә. || Кош яки зуррак бөҗәк еш-еш, кинәт-кинәт канат какканда яки ат пошкырганда чыккан тавышны белдерә. || *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Бу кызыкка күп булып җыйналган хатын-кызлар пырх-пырх көлгәргә тотындылар.* Г. Бәшировв.

Пырх-пырх итү (килү) — 1) шундый тавыш чыгару; 2) шундый тавыш чыгарып еш-еш, кинәт-кинәт көлү. *Мин шундук көлүдән туктадым, башны югарырак күтәрдем, әле һаман пырх-пырх килеп барган Сонягa җиңелчә генә шелтә ясап алдым.* Н. Фәттах.

ПЫРХЫЛДАУ *ф.* Пырх-пырх килү. *Карт имәннең калын ботагыннан пырхылдап урман тавыгы кузгалып китә.* Ф. Хөсни. [*Хатын*] *түзә алмыйча пырхылдап көлеп җибәрде.* А. Шамов. ‖ Пырх-пырх итеп көлү. [*Солдатлар*] *бөтен казарма эчен яңгыратып пырхылдадылар.* К. Нәҗми. *Йөкче мәзәк кенә пырхылдады.* А. Гыйләҗев.

ПЫРЫЛДАВЫК *с.* Пырылдый торган.

ПЫРЫЛДАТУ *ф. сөйл.* **1.** Пыр иттерү. [*Карт*], *каты пырылдатып, борынын сеңгерде.* Ш. Камал.

2. Бик каты ачулану, тиргәү.

ПЫРЫЛДАУ *ф.* **1.** Пыр иткән тавыш чыгару. *Машина пырылдап күздән югалды.* М. Хөсәен. *Чәчәкләр арасыннан күтәрелгән тургайлар чиксез киң зәңгәр күктә пырылдап очалар.* Г. Бакиров.

2. Бер урыннан икенче урынга җиңелчә пыр иткән тавыш чыгарып очу. *Аның аяк тавышыннан куркып, алабута арасында чыпчыклар пырылдады.* М. Әмир. *Һавада нечкә һәм якты эзләр калдырып, утлы бөжәкләр очты, май коңгызлары пырылдады.* Г. Әпсәләмов. ‖ *күч.* Бик тиз һәм җиңел генә хәрәкәт итү, йөрү, бию. *Бу кыз шундый җитез бөтерелә, шундый җиңел пырылдый, ул миңа абый ясап бирә торган салам курчак биюен хәтерләтте.* Г. Бәширов.

3. *күч. сөйл.* Ярсу, тиргәү, дулау. *„Йөремә“, ди-ди „ырылдап“,* [*Ирең*] *тиз үк әйләнер пырылдап, Ятыр да йоклар гырылдап.* Г. Кандалый. *Мәликә тыштан пырылдап керде дә, ачуланып, кулындагы кашыгын казан өстендәге савытка ташлады.* А. Шамов.

ПЫРЫЛДЫК *с. сөйл.* Тиз ярсып, тиз кызып китүчән. *Пырылдык кеше.*

ПЫСКАК: пыскак яңгыр — томалап ява торган бик вак яңгыр. *Иртән башланган пыскак яңгыр, ничектер озакка сузылмыйча, туктый белде.* Э. Касыймов.

ПЫСКАКЛАУ *ф. сөйл.* Әкрен генә сибәләү (вак яңгыр турында). [*Габделхәй*] *өзлексез пыскаклап торган сөзге яңгырлар җебетеп кесәл иткән балчык өемнәренә кар*[*ый*]. Г. Мөхәммәтшин. [*Яңгыр*] *көне буе пыскаклый бит.* А. Гыйләҗев.

ПЫСКУ *ф.* **1.** Ялкынланмыйча, акрын гына төтен чыгарып яну. *Читтәрәк — кичке ашны пешергәннән соң инде сүнеп бара торган учак пыскый.* Ф. Хөсни. [*Чыбыклар*] *башта бераз пыскып, әче төтен генә чыгарып тордылар, бер-ике минуттан соң гына „гөлт“ итеп кабынып киттеләр.* Г. Иделле. ‖ *рәв. мәгъ.* **пыскып.** Ялкынланмыйча, акрын гына төтен чыгарып. *Зур ялкыннар гына җылы бирә, Пыскып янган утта мәгънә юк.* Ә. Ерикәй. ‖ Ялкыны сизелер-сизелмәс булып яну. *Кечкенә фонарь эчендә сукыр лампа пыскый.* Г. Гобәй.

2. *сөйл. к.* пыскаклау. *Яз булды,* [*ләйсән*] *ява пыскып, карлап.* Дәрдмәнд.

3. *күч.* Бик аз гына, зәгыйфь кенә, сизелер-сизелмәслек дәрәҗәдә булу (тормыш, уй, хис һ. б. ш. турында). *Абдулланың күңелендә моңарчы пыскып кына яткан өмет чаткысы кинәт тагын кабынып киткән.* Э. Касыймов. ‖ Эчтән генә, кешеләргә сиздермичә генә берәр төрле уй, теләк, хис, эш белән мәшгуль булу. [*Шәйхетдин*] *төптә Советка дошманлык ачуы белән пыскый.* Г. Толымбай.

4. *рәв. мәгъ. күч.* **пыскып.** Акрын гына. *Аның сүзләре, эченнән яшереневеп, пыскып елавы тагы йөрәгемә тондыра.* Г. Ибраһимов.

5. *рәв. мәгъ. күч.* **пыскып.** Зур эшләр белән шөгыльләнмичә, бөек фикерләр белән янмыйча, үзалдына гына, төссез, борчусыз (тормыш алып бару турында) *Туйдырды пыскып яшәүләр, Яныпкөясем килә, Яныпкөясем килә дә, Шашып сөясем килә.* Ш. Галиев. *Дусларым бар: ярым янып алар, ярым пыскып яшәй белмиләр.* З. Мансур.

6. *күч.* Үкенү, өметсезләнү, өметсезлеккә бирелү. — *Менә монысы безнең опера ариясе. Яратам шундый героик арияләрне. - - - Пыскыма!* Г. Әпсәләмов. *Хәзер безне шул өч тиен тормый торган балыкчылар да санга тыкмый, нинди хурлыкка калдык, дип пыскыдылар* [*алар*]. Г. Толымбай.

ПЫСКУЛЫ *с.* **1.** Пыскый торган, пыскаклый торган.

2. *физ.* Яктырткыч вак газ бөртекләре хасил иткән. *Пыскулы бушану.*

ПЫСКЫЙ *и. диал.* Сукыр лампа. — *Без малай чакларда, — дип сөйли иде әткәй, — куыксыз лампа — пыскый — яндыра идек. Аңа да керосин җитми* [*иде*]. Р. Ишморат. *Багана башында пыскыйда — чүлмәк савытта чырт-чырт килеп кара май яна.* Н. Фәттах.

ПЫСКЫЛДАУ *ф.* **1.** Пысык-пысык иткән тавыш чыгару (елау турында). *Моңарчы күз яшьләрен көчхәл белән тыеп тоткан карчык кинәт әкрен генә пыскылдап елап җибәрде.* А. Шамов. ‖ Пысык-пысык иткән тавыш чыгарып елау. *Аның колагына пыскылдаган тавыш ишетелде.* Атака.

2. Пыс итеп һава чыгу. *Гармонь күрүгеннән һава пыскылдады.*

ПЫСКЫЛДЫК *с.* **1.** Пысык-пысык иткән тавыш чыгара торган. *Ул тавыш бугазына кургашын кадалган солдатның пыскылдык өнен зур завод эчендәге черки тавышыннан да кечкенә ясый.* К. Нәҗми.

2. *күч. шелт.* Юк кына нәрсәгә дә пысык-пысык итеп, акрын гына елый торган. *Пыскылдык хатын.*

ПЫСКЫТУ *ф.* **1.** Ялкынсыз яндыру, төтәтү. *Күзеннән төтен пыскытып, авызыннан төкерек чәчеп башлады, ди, сүз Капкорсак — туймас күз.* А. Алиш. ‖ *сөйл.* (Тәмәке) тарту, төтәтү. — *И син, чепи күз, трубкаңны пыскытма әле монда.* К. Тинчурин.—*Габдрахман абзый, эче пошканда, челемен пыскытып җибәрә.* Д. Аппакова.

2. *сөйл. эвф.* Сасы ис чыгару, сасыту.

ПЫС-ПЫС *аваз ияр. к.* пысык-пысык. — *Ник дәшмисең, әллә телсезме син? — дигәч, Сәхип пыс-пыс елый башлады.* Г. Ибраһимов.

ПЫСЫК-ПЫСЫК *аваз ияр.* Тавыш чыгарыр-чыгармас, акрын гына елаганда була торган тавышны белдерә. ‖ *рәв. мәгъ.* Тавыш чыгарыр-чыгармас, акрын гына; мышык-мышык. *Түрдәге караваттан кемнеңдер пысык-пысык елавына охшаш бер тавыш килде.* Г. Ибраһимов.

Пысык-пысык итү — шундый тавыш чыгару.

ПЫТ-ПЫТ *аваз ияр.* Мотор эшләгәндә, каты җирлеккә өзек-өзек су тамганда, берәр сыеклык сытылып чыкканда яки ут бер кабынып, бер сүнгәндә чыккан тавышны белдерә. *Хайванның күзеннән пыт-пыт тама, Агадыр кап-кайнар яшьләре.* Н. Думави.

Пыт-пыт итү (килү) — шундый тавыш чыгару. *Өчдүрт тартканнан соң* [*мотор*] *пыт-пыт итеп куйса, бик шөкер инде.* М. Әмир.

ПЫТЫЙ-ПАТЫЙ *с. сөйл.* Сакау. *Пытый-патый кеше.*

Пытый-патый килү *сөйл.* — *к.* пытылдау (2 мәгъ.).

ПЫТЫЛДАУ *ф.* **1.** Пыт-пыт итү.

2. Аңлашылыр-аңлашылмас, сакау сөйләшү; бытылдау. *Тансык аңа җавап итеп үз теленә тагын нидер пытылдый.* Г. Ахунов.

3. *күч. шелт.* Бертуктаусыз сөйләп тору, күп сөйләү.

ПЫТЫМЫР *с. сөйл. шелт.* Бертуктамый сөйли торган, күп сөйләшүчән. || *и. мәгъ.* Шундый кеше. — *Бу кадәр такылдык булырсың икән. Такыл да такыл. Пытыр да пытыр. Нәкъ пытымыр.* Р. Ишморат.

ПЫТЫ-ПЫТЫ *рәв. сөйл.* Бертуктаусыз, күп итеп (сөйләү турында); быты-быты.

Пыты-пыты килү *шелт.* — бертуктаусыз һәм күп сөйләү. — *Пыты-пыты килеп гомер буе пытырдаудан эшнең тәмен белми йөргәнмен икән.* Р. Ишморат.

ПЫТЫРДАВЫК *с. сөйл. шелт.* Бик күп һәм тиз сөйләүче.

ПЫТЫРДАТУ *ф.* Пытыр-пытыр иткән тавыш чыгару. [*Контролёр*] *әллә ниткән тимер каптыргыч белән шул билетны пытырдатып, иясенә кире бирә.* Ш. Маннур.

ПЫТЫРДАУ *ф.* **1.** Пытыр-пытыр итү, пытыр-пытыр килү. *Кайәр суккан ул көймә моторы. Кайчак егерменче тартуда гына пытырдый башлый.* М. Әмир. — *Автомашинамы? — диде миңа Авдеев, елмаеп. —Пытырдый.* Х. Госман.

2. *күч. сөйл.* Бик күп, тиз һәм гадәттә аңлаешсыз сөйләү. *Пыты-пыты пытымыр Пытырдарга тотыныр, Бер пытырдый башласа, Юк качып та котылу.* Р. Ишморат.

ПЫТЫР-ПЫТЫР *аваз иәр.* Мотор эшләгәндә, тукыма ертылганда, аңлаешсыз сөйләгәндә һ. б. ш. очракларда чыккан тавышны белдерә.

Пытыр-пытыр итү (килү) — 1) шундый тавыш чыгару. *Мотоциклның каты гына пытыр-пытыр итеп кузгалып китүе ишетелде.* Ә. Еники; 2) күп һәм аңлаешсыз, тиз сөйләү. *Бу йөгәнсез хатын --- пытыр-пытыр килеп, җыен юк-барны сөйләп, эшсезлек сатып йөри.* Ф. Хөсни.

ПЫФ, ПЫФ-ПЫФ *аваз иәр. к.* пуф-пуф. *Рауза пыф диде, кызыл буяулы ирене белән үчеклəде.* А. Таһиров.

Пыф-пыф итү (килү) — *к.* пуф-пуф итү. *Симерүдән аяк өстенә дә басып тора алмыйча „пыф-пыф“ килеп җирдә яткан чучкаларны --- озак күзәтеп тора алмадык.* Ш. Мөдәррис, Г. Ахунов.

ПЫФЫЛДАУ *ф. к.* пуфылдау. *Паровоз пыфылдаган тавышлар чыгарып* [*тора*]. И. Гази.

ПЫХ *аваз иәр.* Атканда кинәттән чыга торган калын тавышны белдерә. *Габдерәшит ишекне ачып: „Пых!“* — [*ди*]. М. Фәйзи.

Пых итү — 1) шундый тавыш чыгару. — *Пых итеп сине куркыттым.* М. Фәйзи. *Ни өчендер пых итеп ат та туктады.* Ф. Кәрим; 2) *сөйл.* берәр җанлы нәрсәне сую. — *Гөлле абыстай! Сыерыгызны суябыз! Пых! итәбез.* Г. Иделлe.

ПЫХ-ПЫХ *аваз иәр.* Авыр сулаганда, атканда һ. б. очракларда чыга торган өзек-өзек калын тавышны белдерә. *Мин барыбер аны кулыма алмыйм, яткан җиреннән генә тамак астын кытыклыйм да пых-пых көлдерәм.* М. Әмир.

Пых-пых итү (килү) — шундый тавыш чыгару. *Эргәсеннән үтеп китәр хәл юк,* [*Каз*] *пых-пых итеп үрелә чукырга.* Ш. Бабич. *Нугай, пых-пых итеп, үзе юына, үзе кызны күзәтә.* Ә. Шәмин.

ПЫХЫЛДАУ *ф.* Пых иткән тавыш чыгару. [*Каз*], *калку күкрәкләрен горур киереп, пыхылдый-пыхылдый җим эзли.* М. Хөсәен.

ПЫЧАК *и.* **1.** Әйбер кисү, турау өчен бер башына сап куелган үткен, яссы металл кисәге. *Чалгы пычак. Чыра пычагы. Пычак йөзе. Пычак сабы. Үтмәс пычак.* □ *Сары бишмәтле итче, кулына пычак алып, бер күй суя башлады.* Г. Тукай. *Булат алдындагы суык каз итен кискәләргә пычак сорап алды.* Г. Ибраһимов.

2. Берәр төрле машина яки эш коралының кисү, турау өчен махсус детале. *Сабан пычагы.*

3. *кис. мәгъ. күч. сөйл.* **пычак, пычагым.** Җәмләдән аңлашылган эш-хәрәкәткә ачулану катыш ризасызлык төсмере биреп, эш-хәлнең юклыгын яки барлыгын белдерә. [*Якуп:*] *Ә! Хәйруллин әхмәтша! Белəм, белəм.* [*Хәбиб — читкә:*] *Белəсең пычагым!* Р. Ишморат. [*Василий Дмитрич:*] *Сез ул акчаларның нинди ихтыялекләрен күрдегезме?* [*Гөлҗиһан:*] *Күрдем.* [*Сиражәтдин үзалдына:*] *Күрдең пычак, ул вакытта инде ул акчалар күптән кладавайда яталар иде.* Г. Камал.

4. *күч. сөйл.* **пычагыма.** Ачулану катыш ризасызлык төсмере белән: нигә, ни өчен.— *Тыңларга телəмəсəң, ни пычагыма чакырдың алай булса!* А. Шамов. — [*Авыруны*] *белмəгəч, пычагымамы доктор булып йөрергə!* Ш. Камал.

5. *күч.* Кемгә дә булса зур уңайсызлык, авырлык, начарлык китерә торган нәрсә. *Бүгенге шикелле нервлары кузгалган вакытларда* [*хатынның*] *пуфылдавы аңар пычак.* Ш. Камал.

◇ **Пычак астына керү (яту)** — 1) операциягә яту; 2) суелу (терлек, кош-корт турында). *Берсеннән-берсе матур утыз-утыз бишләп каз озакламый пычак астына ятачаклар.* И. Гази. **Пычак астында** — операция вакытында. **Пычак белән кисеп алышлы (алырлык) караңгы** — бик караңгы, дөм караңгы. — *Ничек таныйсың, кызым, пычак белән кисеп алышлы караңгыда?* С. Рафиков. **Пычак белән кырып юарлык** — бик керләнгән, пычрак килеш йөргән кеше турында. **Пычак кайрау** — кемгә дә булса янау, ачу саклау, үч саклау, берәр дошманлык эш-хәрәкәте ясарга жыену. — *Карале, Тимергали абый, — диде ул, артык тәкәллефләнмичә, — син нәрсә анда начальствога каршы пычак кайрыйсың?* А. Расих. **Пычак кергере** *тирг.* — әрләү, нык ачулану катыш ризасызлык белдерү өчен әйтелә. *Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергере!* Г. Тукай. — *Әбәү! ...Пычак кергере, башымны яра яздыы...* К. Тинчурин. **Пычак кергән (нәрсә)** *тирг.* — елаган, кычкырган баланы тиргәү өчен кулланыла. **Пычак керү** — 1) елаганны яки кычкырганны яратмыйча әйтелә. — *Пычак кердеме әллә, шул тикле акырасың? — диде ул, коры гына итеп.* В. Нуруллин; 2) үтерелү, кадап, суеп үтерелү. *Пычак кергән җиһанның барча сандугачына!* Г. Тукай. **Пычак кирәкме** *шелт.* — тагы нәрсә җитми, тагын нәрсә кирәк (берәр нәрсәне азсынуны, комсызлануны һәм, гомумән, нәрсә булса да сораганны яратмауны белдерә). — *Артыгын каян аласың? --- Тагын пычакмы кирәк үзегезгә?* Ш. Камал. **Пычак та, пычагым да** — берни дә, бернәрсә дә; берничек тә, һич. *„Әти: „Пычак та булмас!“ — дип кул гына селекте.* Ш. Маннур. *Синең яшьтәшләреңнең борыннарын мышкылдатып карап утырудан, теш казналарын уйнатудан башка пычагым да белмиләр.* Г. Бәширов. **Пычак тел** — үткен, ачы телле кеше турында. *Син әйтәсең: „Пычак тел син“, — дисең... Пычактан да яман минем тел, Пычак үтмәсләнә, кискән саен Үткерләнә бара минем тел.* Ә. Фәйзи. **Пычак телле** — үткен, ачы телле. *Пычак телле тәнкыйтьчеләр — начар халык.* Г. Афзал. **Пычакка алу** — пычак белән кадау, сую. *Этен алдым пычакка, Кызын алдым кочакка.* Такмак. **Пычакка пычак** — үзара килешмәслек, гомерлек дошман. [*Хөббе*] *күптән инде бар кардәшләре — якыннары белән дә пычакка пычак әчелешле булып беткән.* Р. Төхфәтуллин. **Пычакка пычак килү** — 1) бик ныктиргәшү, кычкырышу яки бәхәсләшү. *Зыя белән Фәхри пычакка пычак килешкән хәлдә торганда, агач арасыннан --- бер адәм килеп чыкты.* Г. Ибраһимов. *Әнә шул тынгысыз җан дөнья галимнәре белән пычакка пычак килә, үзенчә уйлап, үзенчә фикер йөртеп,*

үзенчә исәпли башлый. Г. Ахунов; 2) килешмәслек, гомерлек дошман булу.— *Алар пычакка пычак каршы килә торган ике сыйныфны бергә катыштырмакчы булалар.* Г. Коләхметов. [*Кулакның*] *калганы да аз түгел.* --- *Пычакка пычак килеп ятабыз.* Э. Касыймов.

ПЫЧАКЛАШУ *ф.* Пычаклар тотып сугышу, пычаклар белән чәнчешү.

ПЫЧАКСЫЗ: пычаксыз сую — кемне дә булса бик авыр хәлгә кую, һәлак итү. *Әйтергә генә ансат: ярты ел! Бу бит, ни бит... пычаксыз сую белән бер бу.* Г. Ахунов. *Эчендәген белеп булмый, Шунысы пычаксыз суя.* М. Җәлил.

ПЫЧКЫ *и.* Агач, металл һәм таш кисү өчен бер ягы тешле, озынча яки түгәрәк, яссы корыч кисәгеннән гыйбарәт корал. *Аркылы пычкы. Кул пычкысы. Буй пычкы. Пычкы тешен үткерләү. Электр пычкысы.* □ *Ике малайның, кузлага салып, озын пычкы белән әрдәнә тураганнарын күрдем.* Г. Галиев. *Кайдадыр такта яралар, ахрысы, түгәрәк пычкы зырылдавы ишетелә.* Г. Әпсәләмов.

Пычкы станы — *к.* кузла (2 мәгъ.). **Пычкы читле яфрак** *бот.* — кырыйлары пычкы тешләренә охшаш яфрак (мәсәлән, кычыткан яфрагы). **Пычкы чүбе (оны, вагы, ярмасы)** — пычкы белән киселгән нәрсәнең ярма сыман яки порошок сыман калдыгы. *Мирхәйдәр абзыйга, --- такта арасына пычкы вагы тутырып, өстәмә бүлмә ясарга туры килде.* Ә. Фәйзи.

◇ **Пычкы сораганга ышкы тоттырган** *шелт.* — сораганны үтәмичә кирәкмәс нәрсә биргән; кирәкмәс, бөтенләй башка нәрсә эшләгән (кеше турында).

ПЫЧКЫ-БАЛЫК *и. зоол.* Озынча борынында пычкы тешләренә охшаш үсентеләре булган эре, ерткыч диңгез балыгы; *русчасы:* пила-рыба.

ПЫЧКЫЛАУ *ф.* Пычкы белән кисү. *Әллә берәрсе шуның күчәрен пычкылап, аннары шуны минем балаларга күрсәткәнме?* С. Баттал.

ПЫЧКЫЛДАУ *ф.* Чиләнеп, суланып тору; җылыда сүле агып тору. *Юештә ит пычкылдый.*

ПЫЧКЫЧЫ *и.* Пычкы белән урман кисүче, утын кисүче, такта яручы эшче. *Пычкычылар, шул тамгаларга карап, бүрәнәне төрле зурлыктагы өлешләргә кисәләр.* Г. Әпсәләмов.

ПЫЧКЫЧЫЛЫК *и.* Пычкы белән урман кисү, утын кисү, такта яру һөнәре. *Безнең авылыбызда балтачылык, тегүчелек, пычкычылык кеби вак һөнәр ияләре* [*бар*]. Шура.

ПЫЧРАК *с.* **1.** Юешләнеп йомшарган, җепшегән; быкырдык. *Пычрак урамнар. Пычрак кырда футбол уйнау.* || *и. мәгъ.* Юешләнеп йомшарган җир, туфрак, сыек балчык; быкырдык. *Малайлар ишек алдындагы пычрактан „бәлеш“ ясап, аны һавага чөеп йөриләр.* А. Шамов. *Атлар үзле пычракны изә-изә атлый башладылар.* Г. Гобәй. *Яңа бистәнең атаклы көзге пычраклары башланды.* Ә. Фәйзи. | *хәб. функ. Юл пычрак. Тарантас тәгәрмәчләренә уралган сагызлы балчыкның авырлыгы арта бара.* К. Нәҗми.

2. Саф, чиста булмаган, балчык, һәртөрле шакшы катнашкан. [*Гаҗәби*] *аннан су китертә, идән себертә, пычрак суларын түктерә.* М. Гали. *Тояк астыннан атылган пычрак кар кисәкләре кешеләрнең өстенә чәчрәп калды.* И. Гази. || Тузан-туфрак яки һәртөрле шакшылар белән капланган. *Кешеләр пычрак, сасы төрмәләрдә үзләрен үзләре үтерәләр.* Урал.

3. Керләнгән, пычранган, шакшы. *Пычрак алъяпкычлы, начар киемле малай керә.* Г. Камал. — *Өстем пычрак, юынырга-киенергә әмәлем юк.* Ғ. Ибраһимов. || Тәнне, киемне пычрата, буяый торган. *Пычрак эшне ташлаек, дәрәт сата башлаек.* Мәҗәк. [*Алар*] *көне буе җылыда, чиста өйдә тораллар, авыр, пычрак эш эшләмиләр.* М. Гали.

4. *күч.* Кабахәт, бозык, җирәнгеч, әхлакка сыймый торган. *Бу вакыт аларда кызга карата һичбер керле, пычрак уй булмый.* А. Әхмәт. — *Шундый пычрак тәкъдимне ачыктан-ачык ясарга ничек йөрәгең җитте?* А. Гыйләҗев. || *и. мәгъ.* Кабахәтлек, бозыклык, җирәнгечлек, әхлакка сыймый торган нәрсә. [*Батырхан*] *Бибизәйния хакында бик күп пычраклар тараткан.* Г. Ибраһимов. *Безнең остазларыбыз, коммунизмга иске җәмгыятьнең пычрагын сөйрәп бармаска, кешене аннан арындырырга кирәк, дип өйрәтәләр.* Г. Бәширов.

◇ **Пычрак ату (ташлау, ыргыту)** — кемгә дә булса яла ягу, гөнаһсызга кемнең дә булса яман атын чыгару. *Гайкин, Айрат коткысына бирелеп, комсомол бюросына пычрак атканы өчен редакторлыктан алынды.* Г. Ахунов. — *Бернинди дә интригә корган кеше юк, Сәрвәрев. Син пычрак ыргытма!* Р. Ишморат. — *Шушы яшемә җитеп, мин берәү өстенә дә яла якканым, пычрак ташлаганым юк.* Ә. Фәйзи.

ПЫЧРАКЛЫК *и.* **1.** Пычрак булу. *Госман бу урамның яз-көз көнендәге пычраклыгыннан йөдә*[*де*]. А. Шамов. *Балакларның пычраклыгы кыяфәткә бераз зарар итәр.* Ш. Камал.

2. *күч.* Кабахәтлек, эшәкелек, түбәнлек. *Әбдүш күп кенә пычраклыклар эшли, бөтен доносларын расланмыйча кире кайта.* Ф. Хөсни. *Ул улы белән килене арасын бозылыштыру юлында дөньяда булган пычраклыкларны эшләүдән кире тормый.* М. Гали.

ПЫЧРАНУ *ф.* **1.** Янгыр яки юеш кар явып, җир өсте, туфрак, балчык изрәү. *Аяк асты бик нык пычранган, кайбер урыннарда тротуар өсте тоташ боламык хәленә килгән.* А. Шамов.

2. Пычракка буялу. *Әйе, пычрандылар балалар, ләкин моның белән уңышны бик күп күтәрделәр.* Г. Гобәй. *Газинурның ботинкасы чыннан да пычранган иде.* Г. Әпсәләмов. || Каралу, керләнү. *Пычранып беткән ашъяулык алыштырылды.* Г. Ибраһимов.

3. *күч. сөйл.* Эшәке, кабахәт, түбән җанлы кешегә яки шундый эшкә бәйләнү, катнашу. — *Кирәкми, эти, пычранма.* [*Алпавытның*] *урман каравылчысы булу бик начар хезмәт ул.* Т. Гыйззәт. — *Нигъмәтләр белән пычранма! Алар кара сөрем хәзер!* Г. Ибраһимов. || Хурлыклы хәлгә калу. *Баязитов кандидатурасы, --- исеме пычранган кеше булучылыгы белән, аннан артта торадыр.* Ф. Әмирхан. — *Мин сеңелемнең хур булмавы, фамилиянең пычранмавы --- юлында кулымнан килгәнне кызганмый эшләргә вәгъдә бирәм.* М. Фәйзи.

ПЫЧРАТУ *ф.* **1.** Пычракка буяу, пычрак тиерү. — *Урамга чыгарыр хәл юк* [*малайны*], *я кыйнап кертәсең, я өстен-башын пычратасың.* А. Шамов. *Сәҗидә апа, идәнне пычратмаска телӛп, аяк астына карап алды.* Ә. Еники.

2. Чисталыгын югалту, шакшылату. — *Әй, хәерче команда! Пычратма коены!* Г. Бәширов. || Керләндерү, каралту. — *Син аларны югалтма, пычрата күрмә инде алайса, бик кадерле китаплар алар, улым.* М. Гали.

3. *күч. сөйл.* Яхшы исемгә тап төшерү, хурлау, абруен төшерү, яман атын сату. *Тарихи тәҗрибә бу: бик күп пычрак җанлылар олы җанлыларны шулай пычрата алдылар.* С. Баттал. — *Саботажник дип партия алдында пычратырга теләвегез, юк, батмас.* Р. Ишморат.

4. *күч.* Пычрак итеп, кәкре-бөкре хәрефләр белән язу-сызу. — *Мә, читкә алып китеп пычрат алайса,— дип, Габдеһасыйр аңа кәгазь белән кара һәм каурый каләм бирә.* М. Гали.

ПЫЧТЫРДАТУ *ф.* Пычтыр-пычтыр китерү. *Урамдагы суларны, юеш балчыкларны пычтырдатып килгән грузовик капка төбенә туктады.* Г. Кашшаф.

ПЫЧТЫРДАУ *ф.* **1.** Пычтыр-пычтыр килү. *Юлда сыек ләпек пычтырдый.* Н. Фәттах.

2. *күч. сөйл.* Берәр эшне (гадәттә савыт-саба, кер юу, аш пешерү һ. б.) белән шөгыльләнү. (Яратмау төсмере белән кулланыла.) [*Ул*] *мичкә яга, икмәк сала, су җылыта, тагын шунда әллә нәрсәләр белән пычтырдый.* М. Әмир.

ПЫЧТЫР-ПЫЧТЫР *аваз ияр.* Сай судан, пычрактан барганда яки су акканда, суда берәр нәрсә әйләнгәндә, сыеклыкка, пычрак урынга су тамганда чыккан тавышны белдерә. || *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Пычтыр-пычтыр яңгыр ява.* А. Расих.

Пычтыр-пычтыр килү (итү) — **1)** шундый тавыш чыгару; **2)** *күч. сөйл.* вак, кечкенә эш белән шөгыльләнеп тору.

ПЫЧЫНКЫ *с. диал.* Лычкылдык, чиле-пешле (икмәк турында). *Яшелләтә урган ашлыкның камыры пычынкы була, диләр.* К. Насыйри.

ПЫЧЫРГЫ *и. махс.* Ат һәм мөгезле эре терлекнең аягында була торган юеш тимрәү; *русчасы:* мокрец.

ПЫШ *аваз ияр.* Берәр утлы нәрсә суга тиеп сүнгәндә, берәр утлы яки кызган нәрсәгә су сипкәндә чыккан тавышны белдерә.

Пыш итү — **1)** шундый тавыш чыгару; **2)** *күч.* зур тавыш күтәреп башланган эш тәмамланмыйча тукталу. *Кемнәрдер оештырып йөргән бу конференция дигәннәре, казённый бер эш буларак, халыкны үзенә җәлеп итә алмыйча, пыш итеп кенә калмасмы?* Ә. Еники. *Чая сибелә башлаган шушы сатира уты кайдадыр бер урында пыш итеп сүнеп кенә калмаса ярар иде.* Ф. Хөсни.

ПЫШКЫЛДАУ *ф.* Пышык-пышык итү. *Ни өчен әкрен генә пышкылдап елады икән* [*ул*]*?* Г. Галиев. || Акрын гына үзалдына елау; мышкылдау. — *Нәрсә пышкылдап утырасың? Бар, сыерларны сау!* А. Шамов.

ПЫШКЫ(Р)ТУ *ф. сөйл.* **1.** Гадәттә төтенне күп итеп чыгарып тәмәке тарту. [*Институтка*] *алынмаучыларның сары сагышка батып тәмәке пышкыртуларын (йөрәк янганчы тәмәке яңсын!) - - -* [*Хәлим*] *оныта алырмы икән?* И. Гази. [*Дпрәй*] *челемен суырып, төтенен ашыкмый гына бер пышкытып җибәр*[*де*]. Ш. Маннур.

2. *диал. күч.* Аңуланып, тиргәп куркыту.

ПЫШЛЫГУ *ф. диал.* Гадәттә эссе көнне калын кием киеп каты тирләү.

ПЫШ-ПЫШ *аваз ияр.* **1.** Шыпырт кына сөйләшкәндә чыккан тавышны белдерә. || Паровоз һ. б. ш. пар чыгарганда, авыр сулаганда, елаганда һ. б. очракларда була торган тавышны белдерә. || *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. — *Мәҗлестән аерылып, икәү пыш-пыш кына сөйләшеп утырасыз...* Г. Ибраһимов. *Дни пыш-пыш елый башлады.* М. Гафури. [*Искәндәр*] *пыш-пыш трубкасын тарта башлады.* Г. Гобәй.

2. *и. мәгъ. сөйл. шелт.* Пышылдап, шыпыртлап сөйләшү. — *Без киткәч сөйләшерләр. Без бит монда аларның пыш-пышларын тыңларга килмәгән.* Г. Насрый. [*Абдулла*] *берничә кешенең ара-тирә пышылдашып алуларын гына тоеп ятты. Хәер, аның ул пыш-пышка артык исе китмәде.* Э. Касыймов.

Пыш-пыш итү (килү) — шундый тавыш чыгару. *Кемдер бүген минем колагыма, Пыш-пыш килеп, Динле өйләрнең Кичә төнлә, сәхәр утын ягып, Уразага керүен сөйләде.* М. Җәлил. *„Хуш! Хуш-ш!" дигән кебек пыш-пыш килеп Поезд әкрен генә кузгалды.* Б. Рәхмәт. [*Гафур*], *язу өстәлем янына килеп, пыш-пыш итеп тәмәке тарта.* Г. Газиз.

ПЫШТ, ПЫШТ-ПЫШТ *аваз ияр.* Пар яки берәр нәрсә кинәт кенә пышылдап чыкканда барлыкка килгән тавышны белдерә.

Пышт итү, пышт-пышт итү — шундый тавыш чыгару. *Ярлының җаны пышт итеп чыга, Байның җаны шарт итеп чыга.* Мәкаль. *Чиләк астындагы бәрәңгеләр ярыклардан пышт-пышт иттереп пар ат*[*алар*]. М. Шабаев.

ПЫШТЫК I *с. диал.* Эшне акрын эшләүче, мыштырдык.

ПЫШТЫК II *с. диал.* Кысан, тыгыз. *Пыштык бүлмә.*

ПЫШТЫК III *с. диал.* Тыңкыш. *Пыштык кеше.*

ПЫШТЫК-ПЫШТЫК *рәв. сир. к.* мышык-мышык. *Пыштык-пыштык борынын тартып әнисе килеп җитәр.* Г. Сафиуллин.

ПЫШТЫН *с. һәм рәв. диал.* Шыпырт, шыпыртлап. *Кайсыдыр пыштын гына: „Үзләре ишетерләр, бик кычкырмагыз", — диде.* Г. Толымбай.

ПЫШТЫРДАУ *ф.* **1.** Пыштыр-пыштыр килү. *Халык пыштырдый башлады. Күп тә үтмәде, шаулаша башладылар, ул арада булмады, кычкырыша да башладылар.* М. Әмир.

2. *сир. шелт.* Акрын эшләү, мыштырдау.

ПЫШТЫР-ПЫШТЫР *аваз ияр.* **1.** Кыштырдау яки мышкылдау катыш пыш-пыш итүдән, пыш-пыш сөйләшүдән гыйбарәт тавышны белдерә. || *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып. *Балалар яткан җирләреннән пыштыр-пыштыр әллә нәрсә укыйлар иде.* Г. Рәхим.

2. *рәв. мәгъ. к.* мышык-мышык. *Карчык пыштыр-пыштыр елый иде.* Ш. Камал.

Пыштыр-пыштыр итү (килү) — шундый тавыш чыгару. — [*Ул*] *төн буена авыз эченнән пыштыр-пыштыр килеп утыра.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

ПЫШТЫРТ(ЫН) *рәв. сир.* Шыпырт, шыпыртлап, пышылдап.

ПЫШЫЙ-ПЫШЫЙ *рәв. сир. к.* пыш-пыш (1 мәгъ.). [*Ул*] *докторларның үзеннән яшеренеп пышый-пышый гына* [*сөйләшүләрен белә*]. Ш. Камал.

ПЫШЫК-ПЫШЫК *аваз ияр.* Акрын гына, яшерен генә елаганда чыккан тавышны белдерә; мышык-мышык. || *рәв. мәгъ.* Шундый тавыш чыгарып; сулкылдап. *Дни белән җиңгәи, аның гарип кулына күз салгалап, пышык-пышык елап утыралар.* Г. Бәширов.

ПЫШЫЛДАВЫК *с.* Бик акрын, ишетелер-ишетелмәс. — *Тордыңмы, Һидая? — диде* [*Рәхимә*] *пышылдавык тавыш белән.* Н. Фәттах.

ПЫШЫЛДАУ *ф.* **1.** Бик акрын гына, ишетелер-ишетелмәслек итеп әйтү, сөйләү; шыпырт сөйләшү, шыпыртлап әйтү. *Маһибикә миңа гына ишетелерлек итеп колагыма пышылдады.* М. Әмир. *Гөлләр аның колагына пышылдады: „Юк, Газинур, син фикереңнән кире кайтма".* Г. Әпсәләмов.

2. *рәв. мәгъ.* **пышылдап.** Акрын, шыпырт, ишетелер-ишетелмәс. — *Бу сүзне пышылдап түгел, һәркем ишетерлек итеп сөйләргә кирәк.* Р. Ишморат. *Тимери агай пышылдап сөйләшә белми икән, башын иеп тыңлап торды да, калын тавыш белән бөтен залны гөрләтеп: „Менә тагын, нигә әйтмәскә?" — диде.* Г. Бәширов.

ПЫШЫМ-ПЫШЫМ *рәв. к.* пышын-пышын [*дби*] *кызы белән озаклап пышым-пышым сөйләшә.* Ә. Еники. *Ни өчен алар инде ике-өч сәгатьтән бирле читтәнгә сөялеп пышым-пышым сөйләшеп торалар?* Г. Гобәй.

ПЫШЫН *рәв.* Акыртын, шыпыртлап. *Сафа, бибинең бар кеше таралып беткәч тә пышын гына сора-*

ган үтенеченә кабат йөрмәслек итеп, турылатып [*җавап бирде*]. Л. Хәмидуллин.

ПЫШЫН-ПЫШЫН *рәв.* Кеше ишетер-ишетмәс, шыпыртлап; бик акрын. *Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар.* Ә. Еники. [*Нәфисә*] *алдында ялагайланып, артында пышын-пышын гайбәтен чәйниләр иде* [*ул хатыннар*]. Г. Бәширов.

ПЫШЫН-ЧАШЫН *рәв. сөйл.* **1.** *к.* пышын-пышын. **2.** *с. мәгъ.* Колактан-колакка пышылдап әйтелә торган, имеш-мимеш. *Халык эчендә тагын пышын-чашын сүз китә: „Вафа акларны алып кайтырга дип чыккан икән...“ „Дтрәт китертә икән...“ — ди башлыйлар.* Ш. Маннур.

ПЫШЫ-ПЫШЫ *рәв. к.* пышын-пышын. *Зал халкы, үзара пышы-пышы сөйләнеп, бер-беренә елмаешып куйды.* Г. Ибраһимов. *Җылы гына күрешеп, пышы-пышы нидер сөйләшеп алгач, Зөләйха кире чыкты.* Э. Касыймов.

ПЫЯЛА *и.* **1.** Кварц комына поташ һ. б. кайбер матдәләр кушып эретеп, химик эшкәртеп ясалган үтә күренмәле материал. *Пыяла кайнату. Пыяла эретү. Ватылмый торган пыяла. Сыек пыяла. Табаклы пыяла.* □ *Миңа иртәнге көн өчен пыялалар кисеп куярга кирәк.* Д. Аппакова. || Шундый материалның ватылган, уалган кисәге, ватыгы. *Егетнең битенә вә кулына пыялалар керә.* Г. Тукай. *Палач Трегубов, акылдан шашып, пыяла белән бугазын кисеп, үзен үзе үтергә*[*н*]. Г. Ибраһимов.

2. *с. мәгъ.* Шундый материал ясау белән шөгыльләнә торган. *Пыяла заводы. Пыяла промышленносте.*

3. *с. мәгъ.* Шундый материалдан ясалган. *Пыяла савыт-саба. Пыяла күз.* □ *Мәрьям бәләкәй генә пыяла вазаның төбенә вак-вак кисәкләргә ватып салган шикәр* [*куйды*]. Ш. Камал. || Шундый материал куелган, пыялаланган. *Пыяла түбә.* □ *Пыяла ишектән элгән киемнәр күренә.* Д. Аппакова. *Каршы якта савыт-сабалар тутырылган пыяла шкаф* [*тора*]. Г. Әпсәләмов.

4. Шул материалдан ясалган юка табак яки башка бер формадагы әйбер. *Зурайткыч пыяла. Ике ягы да батынкы пыяла. Күзлек пыяласы.* □ *Яңгыр шыбыр-шабыр бертуктаусыз тәрәзә пыяласына сибәләп торды.* И. Гази. *Йөктә салам берлә төргән бик күп лампа пыялалары бар икән.* Г. Тукай.

5. *диал.* Шешә. *Сыра пыяласы.*

6. *диал.* Тәрәзә. *Зур пыяла.*

7. *с. мәгъ.* Шома, ялтырап торган, көзге кебек. *Агыйдел өстенең пыяла тигезлеге челпәрәмә килде.* М. Әмир.

8. *сөйл.* Өсйөзенә махсус ябышкак сыеклык сыланып, текст яки гади рәсем төшерелгән тоник пыяла (текстларны һәм рәсемнәрне күбәйтеп басу өчен кулланыла); стеклограф. *Без* [*листовканы*] *пыялада бастырып күбәйттек.* И. Гази.

Пыяла басма — шундый прибор ярдәмендә күбәйтеп басу ысулы; стеклография. **Пыяла канат** *зоол.* — *к.* пыялач. **Пыяла кискеч** — пыяла кисә торган, башы алмазлы махсус корал. **Пыяла күбек** *зоол.* — суда яши торган болытның (губканың) бер төре; *русчасы:* стеклянная губка. **Пыяла мамык** — укмаштырылган пыяла сүсеннән гыйбарәт җылы саклаучан җиңел материал. **Пыяла мәрҗән** — пыяладан ясалып җепкә тезелә торган төрле төстәге кыска көпшәчекләр — сәйләннең әре төре. **Пыяла сүсе** — сыек пыяладан ясалган җепсел. **Пыяла төбе** *диал.* — *к.* тәрәзә төбе.

◇ **Пыяла белән түбә ябу** — булмастай эш эшләү (кулдан килмәстәй эшне эшләдем дип мактанучыга карата әйтелә).

ПЫЯЛАЛАНУ *ф.* **1.** Пыяла сыман булу, пыялага охшый башлау; пыяла кебек ялтырый башлау. *Көннәр гел кояшлы, җылы торганга, басуда кар иңгән, утырган, чана юллары пыялаланган иде.* И. Гази. || Пыяла катламы белән махсус каплану. [*Торба*] *нигәдер пыялаланмый гына.* Ш. Бикчурин.

2. Тәрәзәләргә, ишеккә һ. б. нәрсәләргә пыяла куелу. *Корпусларның түбәләре ябылган, ләкин тәрәзәләре пыялаланмаган әле.* А. Расих.

3. *күч.* Җансызлану, хәрәкәтсезләнү (күз турында). *Ул исерә башлаган иде. Аның күзләре пыялалана, төссезләнгән ак чыраенда зәгыйфь кенә алсулык уйный.* Г. Ахунов.

ПЫЯЛАЛАУ *ф.* Тәрәзәгә, ишеккә һ. б. пыяла кую. || Пыяла белән каплау, пыяла астына кую. *Алтынлы рамка эченә пыялалап куелган уставны, иске программаны Сөләйман Сәйфуллин* [*ерта*]. Г. Ибраһимов.

ПЫЯЛАСЫМАН: пыяласыман җисем *анат.* — күз алмасы эчендә хрусталик артындагы үтә күренмәле матдә.

ПЫЯЛАЧ *и. зоол.* Пыяла сыман үтә күренмәле канатлары булган күбәләк, җимеш агачлары корткычы; *русчасы:* стеклянница.

ПЫЯЛАЧЫ *и.* Тәрәзәләргә, ишекләргә һ. б. пыяла куючы эшче. — *Безнең эти пыялачы бит, бик шакылдый.* Г. Бәширов. *Балтачының балтасы китек, пыялачының тәрәзәсе ватык.* Мәкаль.

ПЬЕДЕСТАЛ *и.* **1.** Һәйкәл, колонна, ваза һ. б. ш. әйберләрнең сәнгатьчә бизәлгән нигезе; постамент. *Шинелен җилгә җибәргән берәү Державин һәйкәленең пьедесталына бас*[*ты*]. И. Гази. *Пьедесталга тезеп куелган чүлмәкле гөлләрне күргәч, үрелергә уңайсызланды ул.* Э. Касыймов.

2. *күч. кит.* Җәмгыятьтә тоткан югары урын; дәрәҗә, абруй. *Шагыйрьнең* [*М. Җәлилнең*] *кичереше ил язмышы белән нык бәйләнгән, аның дәрте ясалма түгел, ул үзен пьедесталга куеп сөйләми.* Г. Кашшаф. [*Г. Рәхим*] *аны Иранның борынгы суфый шагыйрьләреннән үк килә торган мәңгелек идеалларны җырлаучы --- романтик пьедесталына бастырды.* Г. Халит.

ПЬЕЗОЭЛЕКТР *и. махс.* Кайбер кристалларны (мәсәлән, кварц монокристалын) билгеле бер юнәлештә кысканда яки сузганда аларның кырларында барлыкка килә торган электр корылмалары.

ПЬЕ'КСА *и.* Чаңгы шуганда кия торган һәм югарыга очлаеп торган махсус ботинка.

ПЬЕ'СА *и.* **1.** Сәхнәдә уйнап күрсәтү өчен язылган драма әсәре. *19 июньдә --- „Хуҗа һәм приказчик“* [*исемле*] *пьеса тамашага куелды.* Г. Тукай. *1912 елда* [*Г. Камал*] *үзенең иң яхшы комедияләреннән „Банкрот“ны һәм „Дәҗҗал“ пьесасын* [*яза*]. М. Гали.

2. Кечерәк музыкаль әсәр. *Рабига туташ композиторның „Ел фасыллары“ дигән пьесасын уйный иде.* А. Расих. *Композитор булу омтылышы аңарда училищены тәмамлап чыкканда гына туды, һәм ул фортепьяно өчен пьеса язып карады.* Ш. Хөсәенов.

ПЭ *и.* „П“ хәрефенең исеме.

ПЭР *и.* Англиядә, Япониядә һәм 1848 елгы революциягә кадәр Франциядә иң югары катлау дворяннарга бирелгән дәрәҗәле исем; шул исемгә ия булган кеше. *Инглиз короле зур аристократларга пэр дигән дәрәҗә бирә һәм өс*[*ке*] *палата шул пэрлардан тора.* Г. Коләхметов.

ПЭРЛЫК *и.* Пэр булу, пэр дәрәҗәсе.

ПЮПИТР *и.* Ноталар, китаплар һ. б. ш. кую өчен озын терәк өстенә авыш тактачык беркетелгән җайланма. *Мин, кадерле укучым, рояль пюпитрындагы нота кәгазьләремне калдырып, язу өстәле янына утырдым.* Ж. Фәйзи.

ПӘДӘР *и. иск. кит.* Ата, эти. *Әхмәтнең пәдәреннән миңа бер хат бар иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Пәдәре вафат булганлыктан,* [*Мөстәкыймовның*] *ярдәмгә җитешәчәк кешесе юктыр.* Г. Камал.

ПӘЕЧ *и. диал.* **1.** Яшь бала башында була торган сары төстәге кутыр; йокылык.

2. Сөтне кайнатканда савыт төбенә, стеналарына утыра торган кызгылт касмак. || Кайнаган сөтнең өстендә барлыкка килә торган майлы кызгылт элпә.

ПӘЕЧЛӘНҮ *ф. диал.* Яшь бала башында сары кутырлар барлыкка килү.

ПӘЙВӘСТӘ *рәв. иск. кит.* Тоташтан, өзлексез, һаман да. *Пәйвәстә аны нәфсем эстәр.* К. Гали.

ПӘЙГАМБӘР *и.* **1.** Төрле дини карашлар буенча: алла теләгән, алла ихтыярын кешеләргә алдан хәбәр итүче һәм төшендерүче изге зат. — *Дй, тәңре, әгәр син* [*мине*] *Исраилгә пәйгамбәр итеп --- җибәргән булсаң, ул кире кавем алтын бозауга гыйбадәт кыла алмас, синең боерыкларыңа буйсыныр иде.* Ф. Әмирхан. [*Алла*] *шунда Нух исемле пәйгамбәргә, Халыкларны дингә өндәргә Кушып, үзенең бер фәрештәсен Вәкил итеп, вәхи* [*хәбәр*] *җибәрә.* М. Гафури.

2. Киләчәкне алдан әйтүче, киләчәк турында алдан хәбәр бирүче зат. *Чыктым алан җиргә, әлван чәчәк, Бәйрәм итә монда җәй ае; Җәй аеның да пәйгамбәре: Иң мөкатдәс булган май ае.* М. Укмасый.

Пәйгамбәр каш — куе озын һәм калын каш. [*Гофрайның*] *пәйгамбәр каш дип йөртелә торган озын кашлары зур күзләр өстендә алга очлаеп, зонт төсле торалар.* Н. Исәнбәт. **Пәйгамбәр тырнагы** — оешма чәчәкләләр семьялыгыннан эфлисун-сары төстәге чәчәкле гөл (аның орлык очлары ярым ай сыман бөкләнеп килгән була); тырнак гөл; *русчасы:* календула, ноготки. **Пәйгамбәр чәчәге** *бот.* — болында үсә торган иссез ромашка; *русчасы:* ромашка луговая.

◇ **Пәйгамбәр сөннәте** *иск.* — эш-фигыльдә, үз-үзен тотышта пәйгамбәрләрдән алынган үрнәк. *Пәйгамбәр сөннәте, ягъни өч чынаяк* [*чәй*] *киттеме, аның өсте астына каплану тавышы ишетелә.* С. Баттал. **Пәйгамбәр яшенә җитү** — 63 яшькә кадәр яшәү, 63 яшьтә булу.

ПӘЙГАМБӘРЛЕК *и.* **1.** Пәйгамбәр булу. — *Туры төш, фаразан, пәйгамбәрлекнең кырыктан бер кисәгедер бит.* Ф. Әмирхан. *Якуп, Гаес кулына керергә торган пәйгамбәрлек мөһерен тартып алып, үзе пәйгамбәр була.* Г. Гобәй.

2. Төрле дини карашлар буенча: алла теләгән, алла ихтыярын алдан әйтеп кую. *Пәйгамбәрлек түгел, минем уяу күңел сизгән, күрәсең.* М. Җәлил. *Гаиптән хәбәр бирү белән пәйгамбәрлек безгә көлке тоела.* А. Тимергалин.

3. Кеше тормышында яки җәмгыятьтә нинди хәлләр буласын алдан әйтеп кую, алдан күрү. *Шагыйрь Гейненың сүзләреннән, пәйгамбәрлегеннән аңлашылганча, --- ул мирасларны себереп түгәчәкләрме?* Г. Ибраһимов.

Пәйгамбәрлек итү (кылу) — 1) алла теләгән алдан хәбәр итү, гаиптән хәбәр бирү. *Коръәндә Мөхәммәтнең нибары бер мәртәбә пәйгамбәрлек итүе, ягъни киләчәктән хәбәр итүе билгеле.* Г. Гобәй; 2) *ирон.* берәр нәрсә турында күрәзәлек итү, алдан күрү, сиземи: *Синең гыйлемең мине пәрванә кылды.* Г. Сәмитова.

ПӘЙГАМБӘРЛӘ'РЧӘ *рәв.* Пәйгамбәрләргә хас булганча. *Горький бөек тарихи вакыйгаларның өлгереп килүләрен, халыкларның язмышын һәм киләчәген пәйгамбәрләрчә алдан ук күргән.* Г. Бәширов.

ПӘЙДА: пәйда булу — килеп чыгу, күренү, барлыкка килү, күз алдына килү. *Дсир Мөхәммәт таш баскычта уйланып утырганда, җирдән үскән төсле, аның каршысында кылычлы, мылтыклы городовой пәйда булды.* К. Тинчурин. [*Аның*] *йөрәгендә бер шатлык, бер сөенеч пәйда була.* Дәрдмәнд.

ПӘК *кис. иск. кит. к.* бик III. *Чуваш хатыннарында, бәгъзан, пәк күркәм гадәтләр* [*бар*]. З. Бәшири. *Сабир хәзрәт* [*бу эшкә*] *пәк оста.* Г. Камал.

ПӘКЕ *и.* **1.** Бөкләнеп ябыла торган кечкенә пычак. *Чалгы пәке. Бакча пәкесе. Пәке сабы.* □ *Тимергали, кесәсеннән бер пәке чыгарып, карандашын очларга тотынды.* Ш. Мөхәммәдев. *Хәлим, уртак пәке белән киртли-киртли, шактый юан бер агач сындырып алды.* Г. Гобәй.

2. Кырыныр өчен махсус, бик үткен корыч пычак; бритва. [*Хуҗа*] *кызыл саплы үткен пәке белән, кодалар килгәнче дип, көзге алдында мыегын кырып маташа.* Г. Ибраһимов. *Мин аңа читтән кайтканда чәч ала торган кызыл саплы пәке алып кайтырга вәгъдә бирәм.* А. Шамов.

3. *диал.* Пычак (1 мәгъ.).

Пәке кадаш — пәкене төрлечә бөкләп яки бөкләмичә җиргә кадаудан гыйбарәт уен. *Нимҗан хәтта шундук җиргә утырып пәке кадаш та уйнап алды.* Г. Бәширов.

ПӘКЕСЫМАН: пәкесыман яфрак *бот.* — үткен очлы, ике йөзле пычакка охшаган яфрак.

ПӘНҖАБИ *и.* Һинд-Европа семьялыгының яңа һинд телләре төркеменә кергән тел. *Хәзерге Пәнҗаб штатында пәнҗаби һәм һинд телләрендә сөйләшүче халыклар яши.* Соц. Тат.

ПӘНҖӘКИ *и. жарг.* Биш яки биш йөз сум. [*Тәге ир*] *бер чиләк йомырка алып килде. Әпипәгә күзен кысып: „Пәнҗәки!" — диде. „Җүн, шалкан бәясе".* Г. Бәширов. — *Шаулама инде, болай булгач, бер пәнҗәкиеңне чыгар гына.* Н. Исәнбәт.

ПӘНҖӘШӘМБЕ *и.* Атнаның дүртенче көне; кече атна көн. *Җәмгыятьнең мәҗлесе киләсе пәнҗәшәмбедә* [*була*]. Ф. Әмирхан.

ПӘП: пәп итү *сөйл.* — үбү (күбесенчә балалар телендә). — *Кил әле, кирәксезгә чәпчеп куйганың өчен бер пәп итеп алыйм әле үзеңне (кочып, үбеп алмакчы була).* Ф. Хөсни. — *Сандугачым, былбылым, кенәрием, бер пәп итим инде?... Кая бер үбим инде?* Сов. әд.

ПӘП-ПӘП: пәп-пәп итү — *к.* пәп итү. [*Кыз*] *Үзенең матур курчагын Кочаклап пәп-пәп итә.* Н. Гайсин.

ПӘПӘ *с. диал.* Телсез, сөйләшә алмый торган. || *и. мәгъ.* Шундый кеше. — *Пәпә телен кем белә? Телсез ни пупаламас!* Ш. Маннур. || Сакау кеше турында.

ПӘРВАЙСЫЗ *с. иск.* **1.** *кит.* Игътибарсыз, ваемсыз, гамьсез, кеше һәм үзе турында кайгыртмаучан. *Чыгып киткәндә, күңел өчен генә булса да, бер җылы сүз әйтмәде бит пәрвайсыз бала.* Ш. Хөсәенов. || *рәв. мәгъ.* Гамьсез, ваемсыз рәвештә. *Егетләрнең күбесе пәрвайсыз кыйшаеп я утырып сүзсез ял итәләр.* А. Расих. || Саксыз, җыйнаксыз.

2. *диал.* Әрсез, оялмаучан, әдәпсез.

ПӘРВАЙСЫЗЛАНУ *ф. иск. кит.* **1.** Игътибарсызлану, гамьсезләнү, кеше һәм үзе турында кайгыртмау.

2. *диал.* Әрсезләнү, әдәпсезләнү, оялмау.

ПӘРВАНӘ *и. иск. кит.* Ут әйләнәсендә очып йөри торган күбәләк; ут күбәләге.

Пәрванә кылу — шундый күбәләккә әйләндерү. *Синең гыйшкың мине пәрванә кылды.* Г. Сәмитова.

ПӘРВӘР *с. иск. кит.* Берәр нәрсәне, эшне сөюче, шул эшкә, шул нәрсәгә тарафдар, шуңа чын күңелдән бирелгән. *Ватан пәрвәр.* □ — *Мин үзем хөррият пәрвәр кеше.* Ф. Әмирхан. *Тәзкирә апа Октябрь революциясенә хәтле шәһәрнең тәрәккый пәрвәр ханымнары арасында иң күренеклесе иде.* К. Тинчурин.

ПӘРДӘ *и.* **1.** Берәр нәрсәне каплап яки аерып тору өчен юка тукыма кисәге. *Кисея пәрдә.* □ *Тәрәзәләргә ак челтәрле пәрдәләр элеңгән.* А. Шамов. *Ул тәрәзәнең пәрдәсен ачып карый.* М. Фәйзи.

2. Элекке заманда йөз каплау өчен хатын-кыз эшләпәсенә беркетелгән үтә күренмәле юка челтәр, тукыма кисәге; вуаль. [*Кыз*] *битендәге пәрдәсен ачты, эшләпәсен төзәтте.* Г. Ибраһимов. — *Унбер яшебездән йөзебезгә пәрдә ябып, үз гаиләбездә генә булса да өстәл янында ашаудан тыеп, песи җәмаягы белән чаршау эченә кудыгыз.* Т. Гыйззәт.

3. Сәхнәне тамашачылар залыннан аера торган зур чаршау. *Мин, яңадан пәрдә алдына чыгып, спектакльнең биш минуттан башланачагы, Галиябану ролендә яңа артистка уйнаячагы турында хәбәр бирдем.* М. Әмир. *Авыр бәрхет пәрдә яңадан ачылды. Артистлар баш иделәр.* Ш. Хөсәенов.

4. Драма әсәренең яки спектакльнең төгәлләнгән аерым бер бүлеге; акт (3 мәгъ.). *Беренче пәрдә.* □ *Ике пәрдә арасында ике елдан артыграк вакыт үтеп китә.* Ф. Әмирхан.

5. *анат.* Тере организмны каплап яки бер әгъзаны икенче бер әгъзадан аерып торган юка, сыгылмалы әлпә, яры. *Үпкә пәрдәсе. Күкрәк-корсак пәрдәсе. Аңкау пәрдәсе.* □ [*Неплюйко*], *колак пәрдәсе ертылмасын дип, авызын ачып ятканда, бомба күтәргән тузан авызына тулып, тончыгып үлә язуын сөйләп утырды.* И. Гази.

6. *күч.* Әйләнә-тирәне каплый, күрсәтми торган нәрсә. *Аксыл томан пәрдәсе. Төтен пәрдәсе. Караңгылык пәрдәсе. Төн пәрдәсе.* □ *Үргә җиткәч, бар да, борылып, буран пәрдәсе артында инде шактый ерак булып күренгән авылга карадылар.* Г. Гобәй. || Берәр нәрсәне, берәр эшне яшерә торган билгеле бер кыяфәт, форма, уйдырма, сәбәп, сүз һ. б. *Кайбер кыюсыз, тартынучан кешеләрдә дә җитдилек пәрдәсенә яшеренү гадәте була.* Ш. Камал. — *Сез монда хәзергә чаклы сөйләүчеләрнең сүзләреннән аларның сезгә бүгеннән хәл кылынырга кирәк булган мәсьәләләрне алга сузып, кичектерү пәрдәсе астында калдырырга теләүләрен күрдегез.* М. Гафури. || Билгеле бер хисне, тойгыны белдерә торган кыяфәт. *Бу сүзләрдән соң Карлыгач-Сылуның кара туткыллы сылу йөзенә, нечкә хәсрәт пәрдәсе белән өртелгән матур, кара күзләренә нур чәчелде.* Г. Ибраһимов.

ПӘРДӘЛЕ *с. сир.* Төп асылы аңлы рәвештә төрле сүзләр астына яшерелгән, ачык булмаган. *Аңа пәрдәле җавап кайтардылар.* Г. Ибраһимов.

ПӘРДӘЛЕК *с.* **1.** Пәрдә (1—3 мәгъ.) өчен яраклы, пәрдә өчен махсус. *Тракторчының яшь хатыны --- тәрәзә пәрдәлек тюль таба алмый йөри икән.* Р. Төхфәтуллин.

2. (Бер, ике яки берничә) пәрдәдән (4 мәгъ.), актан торган. *Миңа Нәмыйк Камалның „Зәваллы чуҗык“ дигән өч пәрдәлек драмасы аерата ошады.* Г. Камал. *„Беренче театр“ комедиясе, бер пәрдәлек кенә әсәр булуына карамастан, гомумән, типларның эшләнеше ягыннан югары урын тота.* М. Гали.

ПӘРДӘЛӘНҮ *ф.* **1.** Пәрдә (6 мәгъ.) белән өртелү, томанлану. *Әллә аның күзләре, шатлык яшьләре белән пәрдәләнеп, ялгыш күрәләрме?* А. Шамов.

2. *күч.* Берәр төрле сүз, күренеш яки нәрсә дә булса артына яшеренү. *Дингә пәрдәләнгән миллионерлар — фабрикантлар, байлар, хуҗалар, сарайларына һәм соборларга карап, иңрәшеп еларлар.* М. Гафури.

3. *күч.* Нинди дә булса хискә, тойгыга бирелү. *Әни, аны юату, аның кайгы белән пәрдәләнгән күңелен ачу өчен, төрле сүзләр сөйли.* М. Гафури.

ПӘРДӘЛӘҮ *ф.* Элпә, газ, болыт һ. б. ш. белән каплау. *Гөлсем апа яшь пәрдәләгән күзләре белән бала атасына мескен карады.* Г. Гобәй.

ПӘРДӘЧЕ *и.* Сәхнәдә пәрдәне күтәреп-төшереп яки ачып-ябып торучы махсус кеше. *Ул арада пәрдәче килеп чыкты. Тиз генә пәрдәне төшерделәр.* А. Расих.

ПӘРИ *и. миф.* **1.** Җеннәрнең матур, гүзәл төрләреннән бер вәкиле. — *Сез матур, сез шәрык хикәяләрендә очрый торган пәри падишаһларының могҗизалы гүзәл кызларыннан да матур.* Ф. Әмирхан. — *Пәри кызы! Ник чыктың да юлларыма, Утлы кызыл гөлләр тотып кулларыңа, Гөлләреңне ыргытып бер елмайдың?* Һ. Такташ.

2. Хорафатлар буенча: кешене аздыра, ялгыш юлга кертә торган (күбесенчә ямьсез) кара көч, җен. *Пәри төсле булып беттек инде, кеше күзенә күренерлегебез калмады.* М. Гали. *Бер җитез гыйфрит җибәрдем мин сиңа, Атланып кил шул пәриңнең өстенә!* Ш. Бабич.

3. *гади с., тирг.* Җиңелчә әрләү сүзе булып кулланыла яки тиргәү сүзләренә кушып әйтелә. *Куштыказый: „Ят! Сузыл! дй, таз пәри!“* Г. Тукай. — *Ничек өлгердең син, сукыр пәри?* И. Гази.

4. *с. мәгъ. күч. гади с.* Берәр нәрсәгә, күренешкә, эшкә чиктән тыш тискәре мөнәсәбәтне белдергәндә кулланыла. *Кайдагыдыр бушлыкта чыннан да ниндидер концерт бирелә, ниндидер пәри музыкасы уйнап тора кебек иде.* Ш. Маннур.

Пәри акбашы *диал.* — акбашка охшашлы, аксыл чәчәкле, тәмле исле үлән; меңьяфрак, ярмабаш; *русчасы:* тысячелистник. **Пәри арбасы** — *к.* дүңгәләк. *Көзләр җитәр, җил чыгар, Пәри арбасы юл чыгар.* Мәкаль. **Пәри какысы** *бот.* — каты басуларда бик күп булып үсә торган, кечкенә яфраклы, сары чәчәкле, сабагы төкле озынча үлән. **Пәри үләне** *бот.* — хайваннарга ашата торган, кузаклы, тармаклы икеяллык үлән; ак тәкәмөгез; *русчасы:* донник белый.

◇ **Пәри авыз** *тирг.* — күп сөйләүче яки зур авызлы кешене тиргәгәндә әйтелә. — *Туктa, туктa, диләр ич сиңа, пәри авыз!.. Балалар ишетер!..* А. Шамов. **Пәри алмаштырган** *тирг.* — бик ямьсез, коточкыч кыяфәтле кешегә карата әйтелә. **Пәри башка, җен башка** — икесе ике төрле, бөтенләй башка (әйбер, эш). — *Пәри башка, җен башка, дигәндәй, юмартлык белән ыштансызлык — икесе ике нәрсә, әнекәш.* Г. Ахунов. **Пәри баласы** — берәр балага яратып яки киресенчә, ачуланып, әрләп әйтелә. **Пәри кебек** — *к.* җен кебек. **Пәри күзе** — сукыр лампа. *Консерв банкасыннан ясалган пәри күзе яктылыктан бигрәк сөрем чыгара.* Г. Әпсәләмов. **Пәри (итеп) күрү** — яратмау. **Пәри табагачы** *тирг.* — ямьсез, шыксыз, озын кешегә карата әйтелә. **Пәри туе** — 1) җил бөтерелүдән барлыкка килгән тузан-туфрак баганасы; тузан өермәсе. — *Иске зират турысында без пәри туе күрдек, имә? Юлның уртасыннан бөтерелеп килә, агай, менә коточкыч! Үзе манара тикле, башы болытларга кереп киткән. --- Үзе зыр-зыр әйләнә.* Г. Бәширов. *Ул да түгел, озын урам буйлап пәри туе чабып узды. Яңгыр тамчылый башлады.* И. Гази; 2) шаушулы, тәртипсез мәҗлес, җыелыш һ. б. ш. турында. **Пәри чабаклаган** — бик ямьсез, шыксыз (кеше турында). — *Егетләр, төкерегез үзләренә, шул пәри чабаклаган, чалыш аяклы кызларга!* А. Шамов. — *Агыйделдә берәр пәри чабаклаган кыз су кергәнсә, шулай ялтырый ул* [*кояш*]. Г. Гобәй. **Пәрие кагылу** *шелт.* — берәр нәрсә белән артык мавыгу, берәр нәрсәгә артык ихлас кую. [*Ул*] *бернәрсә сөйләшми, һаман сәгать, һаман сәгать, әллә инде үзенә сәгать пәрие кагылган.* Г. Газиз. **Пәрие килү (котыру, кузгалу)** — 1) берәр нәрсә белән шөгыльләнү омтылышы көчәю; берәр

нәрсә белән бик нык шөгыльләнү. *Хайсның тагын пәрие котырды. --- Ул яңадан үзенең әлекке экзекуцияләренә тотынды.* Ш. Маннур; 2) берәр нәрсәгә ачуланып, кызып китү. *Карт сүзен бүлдергәнне бер дә өнәми иде, шуңадыр, Ятманов юлына аркылы төшкәч, пәрие кузгалды.* Б. Камалов. **Пәрие кушмау**— киреләнү, үзсүзләнү. **Пәрие сөймәү** — *к.* җене сөймәү. *Вәлит монда килгәннән бирле, ул шулай түзми башлады. Беләсез, әллә нишләп Вәлитне аның пәрие сөйми.* Г. Рәхим. — *Мәзинне пәрием бер дә сөйми.* Әкият.

ПӘРИЛЕ *с.* **1.** Хорафатлар буенча: пәрие булган. *Пәриле өй. Пәриле урын.* ▭ *Үземне хикәя китапларындагы „кергән кеше сәламәт чыкмый торган" пәриле йортта кеби тойдым.* Г. Тукай.

2. *күч. сөйл.* Дуамал, тиз холыксызлана торган.

3. *сөйл.* Аз вакыт эчендә бик күп эшләр эшләп ташлаган (кеше турында).

ПӘРИЛӘҮ *ф.* Котыру, ярсу, дуамаллану.

ПӘРИ-ҖЕН *җыйл. и. к.* җен-пәри. *Былтыр Маймыл Хафизга пәри-җен ияләште.* Г. Тукай. *Тавышым минем бар җир-зәмәннәрне ашар, Дәһшәтеннән тәнреләр, гыйфрит, пәри-җеннәр шашар.* Һ. Такташ.

ПӘРМӘ-ПӘР *рәв. диал.* Бергә-бер, кара-каршы, аяусыз. *Пәрмә-пәр талашу.* ▭ *Хаклык сезнең кулда икән, канга-кан, пәрмә-пәр сугышырга кирәк.* А. Гыйләҗев.

ПӘРӘВЕЗ *и.* **1.** Үрмәкүчнең, табышын аулау өчен, үзеннән чыккан махсус ябышкак сыекчадан кора торган җәтмәсе. [*Үрмәкүч:*] *Мин сиңа хәзер күккә дә, җиргә дә тимәслек шундый бер пәрәвез эрләп, сарып куярмын, син ул җепләргә ничек килеп эләккәнеңне сизми дә калырсың.* Н. Исәнбәт. *Чуалган җепләрен кояшта җемелдәтә-җемелдәтә һавада пәрәвезләр оча.* Ш. Рәкыйпов.

2. *күч.* Шуңа охшашлы бик юка, җиңел әйбер. *Аның итеге астында боз пәрәвезләре челтер-челтер ватыла.* И. Гази.

Пәрәвез миңе *зоол.* — үрмәкүч тәнендә пәрәвез өчен сыекча бүлеп чыгара торган бик кечкенә тишек. **Пәрәвез оясы** — 1) пәрәвездән корылган оя. [*Миңнурый*] *өй эчендәге тузаннарны, пәрәвез ояларын себереп йөри.* Г. Әпсәләмов; 2) пәрәвезләр белән капланган, тузанлы, шапшак урын.

◇ **Пәрәвез кору** — хәйлә тозагы кору. **Пәрәвезгә эләккән чебендәй талпыну** — берәр авыр хәлдән төрле юллар белән котылу өчен файдасызга, юкка тырышу.

ПӘРӘВЕЗЛӘНҮ *ф.* **1.** Пәрәвез белән каплану.

2. *күч.* Сизрәү (тукыма турында). [*Чалбарның*] *тез башлары да пәрәвезләнеп килә.* Г. Гобәй.

ПӘРӘВЕЗЛӘҮ *ф.* Берәр нәрсәне пәрәвез кебек каплау яки чәрдәкләү. *Төнге март салкыны нечкә бозларны пәрәвезләгән.* С. Баттал.

ПӘРӘМИ *и. диал.* Хатын-кыз арасында уен катыш бераз шелтәләп әйтелә торган сүз. *Ит түгел, тозлап куймассың аны, пәрәми.* М. Гали.

ПӘРӘМӘЧ *и.* **1.** Эченә тартылган ит салып, авызын бераз ачык калдырып майда кыздырып пешерә торган камыр ашы. *Симез сарык итеннән пәрәмәч пешердем.* Ш. Камал.

2. Өстенә эремчек, бәрәңге боламыгы сылап пешерелгән түгәрәк камыр ашы, шәңгә. *Эремчек пәрәмәче.* ▭ *Ни өчендер әнинең ипи салган көннәрдә пешерә торган бәрәңге пәрәмәчләре искә төшә иде.* Р. Төхфәтуллин.

3. *ы. мәгъ.* Кинәттән булган яки көтелмәгән эшхәлгә гаҗәпләнеп әйтелә. *Мине күргәч, абзыкай гаҗәпләнүеннән кычкырып дәшә куйды: „Пәрәмәч, син кайдан?"* Ә. Еники.

4. *и. мәгъ. күч. сөйл.* Козырёксыз түп-түгәрәк баш киеме турында. [*Солдатларның*] *башларына козырёксыз кокардалы пәрәмәчләр кигезделәр.* М. Гали.

ПӘРӘМӘЧЛЕК *с.* Пәрәмәчкә җитәрлек. ‖ Пәрәмәч өчен махсус әзерләнгән. *Бибиҗамал апа --- пәрәмәчлек камыр куйды.* Ш. Хөсәенов.

ПӘРӘМӘЧЧЕ *и.* Пәрәмәч пешереп сату белән шөгыльләнүче кеше. *Пәрәмәччеләр, Габделкадыйр Сәгъдиев, Мөхәммәтҗан Галиев вывескалары кеби, медальле вә пәрәмәч сурәте төшерелгән зур вывескалар ясатачаклар имеш.* Г. Тукай.

ПӘРӘМӘЧӘ *и. диал. к.* пәрәмәч (1 мәгъ.). *Яңгыр, яу-яу, иләктән, чиләктән, пәрәмәчә, коймактан.* Такмак.

ПӘРӘНҖӘ *и.* Элекке заманда чит ир-атка йөз һәм буй-сын күрсәтмәс өчен үзбәк һәм тажик хатын-кызлары киеп йөргән һәм йөз капларга ат кылыннан куе итеп ясалган челтәре булган ялган җиңле, озын, билсез киң халат. *Мөслимә урамга чыкканда үзен таныткаслык итеп пәрәнҗә бөркәнеп чыгарга тиеш.* Г. Гобәй.

ПӘРӘ-ПӘРӘ *рәв. диал. к.* пәрмә-пәр. — *Тавык фермасыннан Тәзкирә, миңа [яңасын] калдырмагансың дип, пәрә-пәрә килеп талаша.* А. Расих.

ПӘРӘҮ: Пәрәү хәерчесе *диал. тирг.* — өсте-өстенә йомышка кереп, һәрвакыт нәрсә дә булса сорап йөдәтә торган кеше турында әйтелә.

ПӘТӘМӘЧ-КҮМӘЧ *ы. к.* пәрәмәч (3 мәгъ.). — *Пәтәмәч-күмәч! Кеше бар икән ләбаса, әйтмисең дә!* Г. Ахунов.

ПӘТӘЧ *ы. сөйл. к.* бәтәч. — *Пәтәч, чөгендер белән бәрәңгедән генә катырып эшләгән ләбаса!* Ш. Камал.

ПӘХЛӘВИ: пәхләви язуы *лингв.* — фарсы телләренең яңа эрага кадәрге III гасырдан башлап яңа эраның VII гасырынача кулланылышта булган алфавиты. *Иран патшасы Дарий вакытында Иранның борынгы чөй язуын --- алыштырган пәхләви язуын эшләткәннәр.* Г. Сәгъди.

ПӘХЛӘВӘ *и. махс.* Алты-җиде кат куелган вак, юка төче камыр җәемнәре арасына шикәр комы катнаштырып төелгән кузы төше сибеп һәм соңгы катлам өстенә бал ягып пешерелгән милли ашамлык.

ПӘЧ: пәч иттерү *диал.* — *к.* чәп иттерү. — [*Юләр*] *бу мескеннең битенә пәч иттереп бер уч туфрак бәргән.* Ш. Камал.

ПӘЧКЕЛДӘҮ *ф.* Пәч итеп бәрелү, пәч итеп төшү.

ПӘЧНӘТҮ *ф. диал.* **1.** Егу, бәреп егу.

2. *күч.* Берәр җинаять өчен ерак сөргенгә җибәрү. — *Ат урлап өч кат төрмәдән качкан өчен, Миңлегали агайны сигез елга каторгага пәчнәтерләр.* К. Тинчурин.

ПӘЧНӘҮ *ф. диал.* Егылу, пәч итеп егылу.

ПӘЧ-ПӘЧ *аваз ияр. к.* чәп-чәп. *Балалар, авызларын пәч-пәч китереп, бөтен битләрен, ярты күлмәкләрен буяп ашыйлар.* М. Әмир.

ПӘЧРӘЙТҮ *ф. гади с.* (Күзне) елтырату, чекрәйтү. — *Прилавка өстендә, көн буе оя баскан тавык кебек, күзеңне пәчрәйтеп утырасың.* К. Әмири.

ПӘЧҮ *ф. гади с.* Берәр эш уңышлы тәмамлану. — *Гайнулла, пәчте, малай, литерга кererлек эш бар.* К. Әмири.

ПӘЖӘ, ПӘҖИ *и. диал.* Киндер; киндер сүсе. *Пәҗе тәрәшләү.* ▭ — *Җирән бия камытының чөелдереге пәҗедән икән шул. Яңгыр сәбәпле бик бүртенгән дә, чишеп булмый.* Г. Ибраһимов. ‖ *с. мәгъ.* Шундый сүстән, чүбектән ясалган яки тукылган. *Киеп пәҗи кара күлмәк, --- йөрерсең, и Җәмиләкәй.* Г. Кандалый.

ПӘҖҮ *ф. диал.* Шиңү, йомшару, сулу (яшелчә, үсемлек һәм чәчәкләр турында). *Балтырганнардан --- зур-зур көлтәләр бәйләп, пәҗемәсеннәр өчен салкын*

коелар эченә асып куйганнар. З. Бәширн. *Уң як басудагы игеннәр, күптән яңгыр әсәре күрмәгән төсле, пәжгәннәр.* М. Гафури.

ПӘҺЛЕВАН *и.* Зур гәүдәле, бик көчле кеше; баһадир. *Шул минут чыкты вагоннан пәһлеван, Күтәреп башны арыслан сыман.* Г. Тукай. *Бакый, әтисе кебек үк пәһлеван булмаса да, нык, таза һәм матур егет иде.* Г. Әпсәләмов. || Зур гәүдәле көрәшче. *Һәр мәйданда бәйгене рус алды, Һич батыр каршы тора алмаганнан соң, Пәһлеваннар барчасы калды таңга.* М. Гафури. *Пәһлеван шул чакта көчен күрсәтеп, Җибәрә берүне нык мәтәлләтеп.* Н. Баян.

ПӘҺЛЕВАНЛЫК *и.* Пәһлеван булу. *Аның дию белән көрәшеп йөрүче „Салсал батыр" кебек көлке пәһлеванлыгына каршы киләләр.* Г. Кашшаф. *Пәһлеванлыгы белән генә түгел, гадилеге белән дә бөек кешенең тормышын хәзер дә әкият итеп сөйлиләр.* С. Сөләйманова.

ПӨСКЕРТҮ *ф. сир.* Предметларга газ, төтен, су өрдерү, төтәсләү. *Корсагына көмеш чылбырлап тәре аскан поп, аждаһа кебек ямьсез улап, кулындагы кадилен як-якка айкап, төтен пөскертә.* Н. Исәнбәт.

ПӨСКЕРҮ *ф. сир.* **1.** Төтен, пар чыгарып тору; төтәсләү.

2. *рәв. мәгъ. күч.* **пөскереп.** Бик аз гына, зәгыйфь кенә, сизелер-сизелмәслек дәрәҗәдә генә (тормыш, уй, хис һ. б. ш. турында). [*Г. Коләхметов*] *төрле төсләрдә тулкынланып, пөскереп торучы бер хис әдибе түгел, бәлки корыч [логика] сызыкларыннан барып, хакыйкать эзләүче --- бер фикер әдибедер.* Г. Сәгъди.

ПӨХТӘ *с.* **1.** Бик җыйнак, бик чиста. *Пөхтә кеше.* □ [*Нәфисә*] *Хәйдарнең пөхтә өс-башына, күркәм йөзенә карап алды.* Г. Бәширов. *Бу кунак өе булганга гына түгел, кызлы өй булганга бигрәк тә пөхтә.* Г. Ибраһимов. || *рәв. мәгъ.* Бик җыйнак, бик чиста итеп. [*Чувашлар*] *бер башакны җиргә төшерми, төптән кырып, пөхтә уралар.* З. Бәширн. [*Таһирова*] *чыгышларны, бөтен күңелен куеп, җентекләп язып барды һәм бик пөхтә итеп төплэп китерде.* Г. Ахунов.

2. Җиренә җиткерелгән, төгәл. *Эшебез пөхтә, сүзебез кыска.* Ә. Ерикәй. || *рәв. мәгъ.* Җиренә җиткерелеп, төгәл итеп. [*Батыргали*] *һәрбер алган-сатканны, приходны-расходны язып, эшләрен бик пөхтә йөртә торган иде.* Ш. Мөхәммәдев.

ПӨХТӘЛЕК *и.* Пөхтә булу. *Әнкәй карчык --- чисталык һәм пөхтәлеге --- белән үрнәк итеп йөртелә торган хатыннардан иде.* М. Галәү. [*Бу йорт*] *вакытында бик байлык, бик җитешлек һәм пөхтәлек белән эшләнгән.* Ф. Әмирхан.

ПӨХТӘЛӘНҮ *ф.* Үз өс-башын җыйнакландыру, чистарту. — *Урамга чыгып китәр алдыннан ул пөхтәләнә, ясана башлады.* Ш. Хөсәенов.

ПӨХТӘЛӘҮ *ф.* Пөхтә, җыйнак итү. *Ул пөхтәләп дүртка бөкләнгән кәгазьне бүрегеннән алып Хәлимгә күрсәтте.* Г. Гобәй. [*Кыз*] *конфет кәгазьләрен пөхтәләп төрде.* Д. Аппакова.

ПҮКЕЛДӘҮ *ф.* Пүк-пүк иткән тавыш чыгару. || Шундый тавыш чыгарып эшләү. *Тау башында Бәшир байның көне-төне пар белән эшли торган бик шәп тегермәне пүкелдәп утыра.* Г. Бәширов.

ПҮК-ПҮК *аваз ияр.* Мотор эшләп, билгеле бер ешлыкта көч белән төтен чыкканда яки кечкенә пистолеттан атканда барлыкка килгән тавышны белдерә.

ПҮЛӘН *и. сөйл.* Агач кәүсәсенең ягар өчен киселгән кыска бер кисәге; түмәр, бүкән. — *Пүлән ботаклы булса, нишләрсең?* А. Расих. || Шул бүкәннең балта белән ярылган бер өлеше. *Мич яна. Әсгать аңа аратирә яңа пүләннәр өсти. Пүләннәр, янарга телә мәгәндәй, --- пыскып, бераз чыжлап торалар.* А. Шамов.

ПҮНӘТӘЙ *и.* Берәр кешенең өен тентегәндә, милеген язганда һ. б. ш. очракларда властьлар тарафыннан шаһитлек өчен чакырылган кеше; танык. *Пристав, бүлмәне тентегәч, протоколга кул куйдырып, пүнәтәйләрне чыгарды.* Г. Ибраһимов. — [*Капчыкны*] *пүнәтәйләр алдында келәт идәнегездән алдым.* Т. Гыйзәт.

ПҮНӘТӘЙЛЕК *и.* Пүнәтәй булу. [*Камали*] *фабрикант та була алмас, пүнәтәйлеген дә яшерә алмас.* К. Нәҗми.

ПҮСКЕРТҮ *ф. гади с.* Кая да булса куып җибәрү. *Без дошманның көчле фиркаләрен [көңбатышка] пүскерттек.* М. Галәү.

ПҮЧИНКӘ *и. диал.* Зур авылдан аерылып утырган кечкенә авыл яки гомумән кечкенә авыл. *Сасна пүчинкәсе.*

ПҮЧТӘК *с. сөйл.* **1.** Юк-бар, әһәмиятсез, вак-төяк. — *Сынап торасы да юк, пүчтәк эш белән шөгыльләнәбез без.* А. Расих. *Терәүләр тотмый аны, җир үзен үзе тота. Бу терәүләргә калса, пүчтәк ул.* М. Гафури.

2. *и. мәгъ.* Вак-төяк, юк-бар, әһәмиятсез нәрсә (эш, сүз). — *Пүчтәкне сөйләмә әле, синең соң армиядә бер генә абыең бар иҗ.* А. Әхмәт.

Р

Р Татар алфавитында 17 нче хәреф.

РАББЕ, РАББЫ *и. дини.* Алла, ходай, тәнре. *Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңелем кошы, Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.* Г. Тукай. *Хаким иттең, раббем, җир йөзенә кара көчне — алтын-көмешне.* М. Гафури. || *ы. мәгъ.* **(әй, я, и) раббем, раббым, рабби.** Көчле тойгыларны, кичерешләрне: борчылуны, кайгыруны, кызгануны, кайгы уртаклашуны, үкенүне, нәфрәтне, гаҗәпләнүне, соклануны, шатлыкны һ. б. аңлатканда кулланыла. [*Гөлҗиһан:*] *Кунаклар килер вакыт җиткән, безнең табыннар да хәзерләнеп җитмәгән. И раббем!* Г. Камал. [*Шәмсинур ирене:*] *Тилерәсеңме юкса? - - - Бу нинди йокламаган бәндә икән, я раббем...* С. Рафиков. *Раббым, мин күзләремә ышанмыйм: ул — 16-17 яшьлек бер кыз, бер фәрештә!* Ф. Әмирхан.

РАБФАК *и.* 1919—1930 елларда СССРда: эшче һәм крестьян яшьләрен югары мәктәпләргә керү өчен хәзерли торган гомуми белем бирү факультеты. *Рабфак тәмамлау. Рабфакта уку. Университет рабфагы.* □*Алар рабфакта сыйныфташ иптәшләр.* Ш. Камал. *Бу хатны рабфактагы яшь Комсомол дсгать яза.* Һ. Такташ.

РАБФАКЧЫ *и.* Рабфакта укучы. *Донбасс шахтасыннан килгән рабфакчы яшьләребез кадет профессордан физика, яки химия, яки математика өйрәнгән кебек, эшче-крестьян язучылары да капитализм калдырган ул әдәбият мирасыннан - - - өйрәнәчәк.* Г. Ибраһимов.

РАББИН *и.* Еврейләрнең дини оешмасында җитәкче, өлкән рухани. *Рус побы белән еврей раввины бәхәсләшәләр: кемнең, кайсы диннең алласы халыкка файдалырак?* Каз. утл.

РАВЕЛИН *и. иск.* Борынгы крепостьларда стенаның тышкы ягына чыгарып эшләнгән өстәмә нығытма. *Петропавел равелиннарында Бабам каны тамган ташлар бар.* Каз. утл.

РАГУ *и.* Вак итеп туралган сөякле ит, балык яки яшелчәләрдән тәмләткечләр салып пешерелгән ашамлык. *Пешеп җиткәч, рагуны тәлинкәгә бушатырга һәм вак итеп туралган яшел петрушка яки укроп сибеп табынга бирергә кирәк.* Йорт эшләре.

РА'ДА *и.* **1.** *тар.* Украинада: иҗтимагый эшләр буенча үткәрелә торган халык җыелышы; киңәшмә, җыен. *Мөһим мәсьәләләрне хәл итү өчен, Переяславль шәһәрендә гомуми рада җыела.* СССР тарихы.

2. Украинада һәм Польшада власть органы булган совет (министрлар советы, авыл советы һ. б.).

3. Украина һәм Белоруссия буржуаз милләтчеләренең 1917—1918 елларда яшәп килгән контрреволюцион оешмалары. *Украина Үзәк радасы. Беларусь радасы.*

РАДАР *и. тех. к.* радиолокатор. || *с. мәгъ.* Радарга бәйләнешле: радар(лар)ы булган; радар ярдәмендә барлыкка китерелгән. *Радар җайланмасы. Радар станциясе.*

РА'ДЖА *и.* Һиндстанда феодаль князьләр һәм җирле власть ияләренең титулы; шушы титулга ия булган кеше.

РАДИАЛЬ *с. махс.* Радиус буенча урнаштырылган (юнәлдерелгән, таратылган, тезелгән); үзәктән таралган нур сыман. *Радиаль симметрия. Яңа шәһәрнең радиаль проспектлары.* || *рәв. мәгъ.* Радиус буенча урнаштырылып (юнәлдерелеп, таратылып, тезелеп).

РАДИАЛЬЛЕК *и.* Радиаль булу, радиаль булу сыйфаты.

РАДИА'ТОР *и.* **1.** Моторны су ярдәмендә суыта торган прибор. *Самолет радиаторы. Автомобиль радиаторы.* □*Фәрит Илдарга күз кысты да чиләктән кепкасы белән су алып трактор ның, аннан комбайнның радиаторына салды.* Г. Гобәй. || *с. мәгъ.* Радиаторга бәйләнешле; радиаторлар эшләп чыгара торган. *Радиатор җайланмасы. Радиатор заводы.*

2. Үзәктән ягып җылыту системасында: йортларны җылыту өчен, эчендә кайнар су яки кайнар пар хәрәкәт иткән трубалардан торган җайланма. *Зур тәрәзә астында радиатор. Райком урнашкан йорт үзәктән ягып җылытыла.* С. Рафиков.

РАДИА'ЦИЯ *и. физ.* **1.** Берәр җисемнең электромагнитик энергия таратуы (чәчүе, сибүе); берәр җисем тарафыннан таратылган электромагнитик энергия, нур энергиясе. *Памир грушасының бу гажәеп үзенчәлекләрен галимнәр кояшның кыска дулкынлы радиациясе тәэсирендә нәселдәнлекнең үзгәрә баруы белән аңлаталар.* Соц. Тат. || *с. мәгъ. к.* радиацион. *Радиация поясы.*

2. Нәрсәнең дә булса үзәктән читкә таба нур сыман таралуы (чәчелүе, сибелүе). *Алынган сигналларны өйрәнү күрсәткәнчә, Ай өстендә радиация дозасы тәүлеккә 30 миллиард тәшкил итә.* Соц. Тат.

РАДИАЦИОН *с.* Радиациягә бәйләнешле. *Җирнең радиацион поясы.*

РА'ДИЙ *и.* Радиоактивлык сыйфаты булган химик элемент, металл. *Радий белән дәвалау.* □*Радий — сирәк элемент; бер грамм саф радий аерып алу өчен, иң кимендә 5 т. уран рудасын эшкәртергә кирәк.* Физика. || *с. мәгъ.* Радийга бәйләнешле. *Радий нурлары.*

РА'ДИЙЛЫ *с.* Составында радий булган. *Радийлы су. Радийлы руда.*

РАДИКАЛ I *и.* **1.** Кискен чаралар үткәрүне яклаучы (кеше). [*Әхмәт:*] *Искенең дә арасында яхшылары була. Радикал булган булып, һәммә искене утка ягып бетерер хәлем юк.* Г. Камал.

2. Радикаллык (2 мәгъ.) тарафдары. *Радикаллар партиясе.* □*Парламентка сайлауларда радикаллар, социалистлар һәм аларга якынайган группалар җиңеп чыктылар.* Ин яңа тарих.

РАДИКАЛ II *и.* 1. *мат.* Тамыр алу гамәленең һәм тамыр алу нәтиҗәсенең тамгасы: √.

2. *хим.* (Химик реакция барышында) молекуладагы атомнарның бер химик кушылмадан икенче химик кушылмага үзгәрешсез күчә торган тотрыклы төркеме. *Тәҗрибә - - - кислота радикалларының һәм ОН төркемнәренең тискәре корылмалы булуын күрсәтә.* Физика.

РАДИКАЛЛАНУ *ф. сөйл.* Радикаллык күрсәтү; радикал булган булып күренү (кылану).

РАДИКАЛЛЫ *с. мат.* Радикалга II (1 мәгъ.) бәйләнешле; радикалы булган. *Радикаллы аңлатма.*

РАДИКАЛЛЫК *и.* 1. Теоретик һәм практик мәсьәләләрне хәл иткәндә кискен чаралар үткәрү һәм шуны яклау.

2. Буржуаз дәүләт интересларыннан чыгып һәм шул дәүләт рамкаларында өлешчә демократик реформалар үткәрүне таләп итә торган буржуаз яки вак буржуаз политик агым. *Радикаллык политикасы.* □*Бишенче ел революциясеннән соң, вак буржуа зыялыларының бер өлеше эре буржуа ягына чыгып китсә, икенче бер өлеше иҗтимагый хәрәкәттән кул селтәү, өметсезлеккә бирелү, пассив радикаллык күрсәтү кебек омтылышлар да булды.* Г. Нигъмәти.

РАДИКАЛЬ *с.* 1. Кискен, катгый; тамырыннан, нигезеннән үзгәртелгән.— [*Асиядә*] *порокның иң усалы. Аны фәкать иң радикаль чара — операция генә коткарса коткарыр.* Г. Әпсәләмов.

2. Радикаллыкка (2 мәгъ.) бәйләнешле. *Буржуаз радикаль партияләр. Радикаль караш.* □ [*Анри Барбюсның*] *иҗат юлында без - - - Франция радикаль интеллигенциясенең дөнья сугышыннан һәм пролетариат революциясеннән сабак ала-ала коммунизмга килеп кушылуы чагылганын күрәбез.* М. Җәлил.

РАДИКАЛЬЛЕК *и.* Кискенлек, катгыйлык. *Чараларның радикальлеге.*

РАДИКУЛИТ *и. мед.* Арка мие нерв җепселләренең ялкынсынуы. — *Билегезгә салкын тигән булырга тиеш. Сездә хроник радикулит бар.* Ш. Хөсәенов.

РА'ДИО *и.* 1. Пространствода чыбыксыз тарала торган электромагнитик дулкыннар ярдәмендә ерак араларга сигналлар, тавышлар, сүзләрне һ. б. ш. махсус станцияләрдән тапшыру һәм кабул итү; шул ысул белән элемтә тоту, хәбәрләшү. *Радио дулкыннары. Радио товарлары. 7 май — радио көне.* □ *Таң атканчы камышлыкка кереп шунда көймәне урнаштырырга һәм көндез шуннан күзәтү эшен алып барырга, күргәнне радио аша тылга тапшырып торырга кирәк.* Э. Айдар. || *с. мәгъ.* □ [*Шамил Шәкүров*] *радио эше белән дә шөгыльләнә.* Сов. әд.

2. *сөйл. к.* радиоалгыч. *Нәфисә өстәл өстендәге китапларын караштырды, радионы көчәйтебрәк куйды.* Г. Бәширов. *Халык күбрәк минем радионы тыңларга җыела. Чөнки минем радио буенча телгән бер шәһәрне тыңларга мөмкин.* Г. Кутуй.

Радио алу (тоту) — махсус станцияләрдә радио дулкыннары кабул итү. *Антенналы беренче мәртәбә А. С. Попов уйлап тапкан. Радиолаштыру һәм радио алу эшендә „җирлә“не дә беренче мәртәбә ул кулланган.* Физика. **Радио вышкасы**— радио дулкыннарын тарату һәм тоту өчен махсус биек антенна.

РА'ДИО- I Кушма сүзләрдә радиога (1 мәгъ.) бәйләнешле, радиога караган мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **радиоаппарат, радиотехника, радиоэлемтә, радиоантенна.**

РА'ДИО- II Кушма сүзләрдә радий, радиоактивлык, радиациягә мөнәсәбәтне күрсәтә торган беренче кисәк, мәсәлән: **радиоизотоплар, радиодәвалану, радиоэлемент.**

РАДИОАКТИВ *с.* Радиоактивлыкка бәйләнешле, радиоактивлык үзлеге (сыйфаты) булган. *Радиоактив нурлар. Радиоактив элементлар.* □*Халык хуҗалыгы өчен кирәк булган радиоактив изотопларны реакторлар һәм циклотроннар ярдәмендә алырга мөмкин.* Атом энергиясе...

РАДИОАКТИВЛАШТЫРУ *ф.* Радиоактив итү. *Реактордан чыккан радиоактив нурланыш тирә-юньдәге һавага тарала һәм аны радиоактивлаштыра.* Атом энергиясе...

РАДИОАКТИВЛЫК *и.* Электроннар, позитроннар һ. б. нигез кисәкләрнең нурланышы нәтиҗәсендә химик элементларда атом төшенең үзлегеннән таркалуы яки ясалма рәвештә таркатылуы. *Җир токымнарының радиоактивлыгы.* □*Кюрилар радиоактивлык белән шөгыльләнгәндә, берәү дә аларның эше кешелеккә яңа эпоха алып килә дип уйламаган.* А. Расих. || *с. мәгъ.* Радиоактивлыкка бәйләнешле; радиоактивлык үзлеге, сыйфаты булган.

РАДИОАЛГЫЧ *и. тех.* 1. Югары ешлыклы электромагнитик тирбәнешләр энергиясен тоту, үзгәртү һәм файдалану өчен хезмәт итә торган җайланма. *Ящерен оешма членнары бик кыенлык белән булса да радиоалгыч табалар.* Х. Мөҗәй. || *с. мәгъ.* Радиоалгычка бәйләнешле; радиодулкыннар тоту өчен хезмәт итә торган. *Радиоалгыч антенна.* □[*Самолетлар өчен эшләнгән приказ*] *шифрланган сигналлар рәвешендә самолетка җибәрелә. Биредә ул радиоалгыч җайланмалары тарафыннан кабул ителә.* Уйлаучы машиналар.

2. Радиотапшыруларны тоту, кабул итү аппараты. *Менә сәхнәнең кызыл япкан зур өстәле өстендәге радиоалгыч музыка уйнап җибәрде.* Г. Бәширов.

РАДИОАЛГЫЧЛЫ *с.* Радиоалгычы булган, радиодулкыннарны кабул итә торган. *Радиоалгычлы җайланма.*

РАДИОАППАРАТУ'РА *җый. и.* Радио дулкыннарын тапшыру, кабул итү, үзгәртү өчен кулланыла торган аппаратлар, радио җиһазлары. [*Кәримов*] *радиоаппаратура янына килә, трубканы ала. Сөйли башлый.* А. Әхмәт.

РАДИОБИОЛО'ГИЯ *и.* Радиоактив нурланышның организмга тәэсирен өйрәнә торган фән.

РАДИОГРА'ММА *и.* Радиотелеграф аша тапшырылган хәбәр. *Көннәрдән бер көнне больницага радиограмма килеп төште. Бәхетсезлек, ашыгыч рәвештә хирург чакыралар.* Г. Әпсәләмов. — *Мин сезгә бик мөһим бер радиограмманы күрсәтергә тиеш.* Ш. Усманов.

РАДИОГРА'ФИЯ *и.* Радиоактив элементлар нурланышы тәэсире белән пленкага фоторәсемнәр төшерү методы.

РАДИОДУЛКЫН *и. физ.* Сигналларны ерак урыннарга чыбыксыз тапшыруда кулланыла торган электромагнитик дулкын. *Радиолокатор антеннасыннан чыккан радиодулкыннар, җир өстенә карата почмак ясап, нечкә генә нур бәйләме булып китәләр.* Күкне штурмлау.

РАДИОЗОНД *и.* Зур булмаган һава шары белән атмосферага җибәрелеп, төрле биеклектәге һаваның басымын, температурасын, дымлылык дәрәҗәсен үлчи һәм шул турыда радио буенча автоматик рәвештә хәбәр итә торган метеорологик прибор.

РАДИОКОЛГА *җыйд. и.* Җир өсте радиостанцияләре антенналарын тиешле биеклектә беркетеп, ныгытып куя өчен терәк, мачта. *Өстә — радиоколгалар. Аста — тезелгән торбалар.* Н. Исәнбәт.

РАДИОКОМБАЙН *и.* Телевизор, радиоалгыч, магнитофон һәм пластинка уйнаткычтан торган аппарат.

РАДИОКОММЕНТА'ТОР *и.* Экономика, сәнгать, спорт турында күзәтүләр, халыкара политик күзәтүләр һ. б. ш. турында радиодан сөйләүче; радио аша чыгыш ясаучы, радиорепортаж алып баручы кеше.

РАДИО'ЛА *и.* Радиоалгыч белән пластинка уйнаткычтан торган аппарат. [*Мансур*] *сикереп торып радиоланы борып җибәрде.* Г. Әпсәләмов. *Мәдинә радиола янына килде. Пластинка куйды.* Ш. Хөсәенов.

РАДИОЛА'МПА *и.* Радиоаппаратка куела торган махсус лампочка.

РА'ДИОЛАШТЫРУ *ф.* 1. Радио һәм радиостанцияләр челтәрен киңәйтү, җәелдерү эше.

2. Радио үткәрү, радио кертү, радио җиһазлары белән җиһазлау. *Илне радиолаштыру.*

РА'ДИОЛАШУ *ф.* Радио үткәрелү. *Авылның радиолашуы.*

РАДИО'ЛОГ *и.* 1. Радиология белгече.

2. Авыруларны радиоактив матдәләр белән дәвалаучы врач.

РАДИОЛО'ГИЯ *и.* Радийның һәм башка радиоактив элементларның тәэсирен, алардан файдалану юлларын өйрәнә торган фән. *Радиология кафедрасы.*

РАДИОЛОКА'ТОР *и.* (Эзләнелә торган объекттан чагылган радиодулкыннар ярдәмендә) пространстводагы төрле объектларның урыннарын табу һәм билгеләү җайланмасы. [*Астронавт*] *радиолокатор экранына карап алды.* А. Тимергалин. *Радиолокаторның антеннасы очып баручы самолетны үзенең нуры белән тота.* Уйлаучы машиналар.

РАДИОЛОКАЦИОН *с.* Радиолокациягә бәйләнешле. *Радиолокацион тикшеренүләр. Радиолокацион корылмалар. Радиолокацион күзәтүләр.*

РАДИОЛОКА'ЦИЯ *и.* Радиодулкыннар ярдәмендә төрле объектларны табу һәм аларның ераклыгын билгеләү методы. || *с. мәгъ.* Радиолокациягә бәйләнешле. *Радиолокация станцияләре. Радиолокация техникасы. Радиолокация аппаратлары.*

РАДИОЛОКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Радиолокация эшен башкару. *Айга каты һәм йомшак төшерү өчен автоматлар җибәрү. Айны радиолокацияләү --- кыйммәтле мәгълүматлар бирәчәк.* Соц. Тат.

РАДИОМАЯК *и.* Корабльләр һәм самолетлар үзләреннең кайдалыгын билгели алсыннар өчен махсус сигналлар җибәреп тора торган җирдәге радиостанция.

РАДИОНАВИГА'ЦИЯ *и.* Самолет һәм корабльләрне радиотехник чаралар ярдәмендә йөртү.

РАДИОНАВИГАЦИОН *с.* Радионавигациягә бәйләнешле. *Радионавигацион сигналлар.*

РАДИОНОКТА *и.* Радиотрансляция тапшыруларын кабул итү җайланмасы.

РАДИОПОСТАНО'ВКА *и.* Радиостудиядә куела һәм радио аша тапшырыла торган пьеса яки әдәби инсценировка. *Радиопостановка тыңлау.* □ *Радиопостановкаларның сыйфатын күтәрүдә, аларны төрләндерүдә Камал I зур көч куя.* Сов. әд.

РАДИОРЕПОРТАЖ *и.* Эшнең торышы, вакыйгалар, хәлләр турында турыдан-туры урыннан (заводтан, колхоздан, стадионнан һ. б.) радио аша тапшыру.

РАДИОРУ'БКА *и.* Радист эшли торган һәм радиоаппаратура урнаштырылган эш бүлмәсе (самолетта, корабльдә). *Радиорубкада бик эссе һәм бөркү.* С. Сабиров.

РАДИОРУ'ПОР *и.* Рупор рәвешендәге репродуктор.

РАДИОСТА'НЦИЯ *и.* Радиодулкыннар тарату һәм кабул итү өчен билгеләнгән техник җиһазлар, аппаратлар җыелмасы. || *сөйл.* Радиодулкыннар тарату һәм кабул итү эше алып барыла торган пункт (станция). *Хәзер Эйфель манарасы — дөньяда иң биек радиостанция.* Г. Гали.

РАДИОСТУ'ДИЯ *и.* Радиотапшырулар алып барыла торган махсус җиһазландырылган зал, бина.

РАДИОСӨЮЧЕ *и.* Радиотехника һәвәскәре (радиоалгычлар, телевизорлар конструкцияләүче, ясаучы, радиоэлемтә буенча тәҗрибәләр үткәрүче һ. б.).

РАДИОТАПШЫРГЫЧ *и. тех.* Радио аша тавышлар, сигналлар тапшыру өчен хезмәт итә торган аппарат, җайланма (радиоэлемтәдә, радиолокациядә кулланыла). *Әй бу — автомат-телефон станциясе. Радиотапшыргыч! Аккумулятор!* Соц. Тат. || *с. мәгъ.* Радиотапшыргычка бәйләнешле. *Радиотапшыргыч аппарат.*

РАДИОТАПШЫРУ *и.* 1. Текст, музыка, хәбәрләрне һ. б. ш. радиодулкыннар ярдәмендә (радио аша) ерак араларга тапшыру. *Радиотапшыру программасы. Морзе системасы буенча радиотапшыру.*

2. Радио аша тапшырылган текстлар, музыка, җыр, хәбәрләр һ. б. ш. *Кичке радиотапшыруны тыңлау.*

РАДИОТЕЛЕГРА'ММА *и. к.* радиограмма.

РАДИОТЕЛЕГРАФ *и.* 1. Радио аша телеграмма сугу һәм алу аппаратлары җыелмасы. || *с. мәгъ.* Радиотелеграфка бәйләнешле. *Радиотелеграф аппараты. Радиотелеграф станциясе.*

2. Шушы эшне башкаручы учреждение, станция.

РАДИОТЕЛЕГРАФИ'Я *и.* Билгеләнгән хәрефләр һәм цифрлар белән язылган шартлы сигналларны радио ярдәмендә тапшыру яки тоту, кабул итү.

РАДИОТЕЛЕФОН *и.* Радио аша телефон элемтәсен тапшыра һәм кабул итә торган аппаратлар җыелмасы. *Каналга хезмәт күрсәтә торган станцияләрне үткәндә гарәп лоцманы радиотелефон аша пароходның исемен, кәрвандагы номерын һәм тизлеген әйтә.* Сов. әд.

РАДИОТЕЛЕФОНИ'Я *и.* Элемтә һәм культура максатлары белән радио аша хәбәрләр, музыка һ. б. ш. тапшыру һәм кабул итү.

РАДИОТЕРАПИ'Я *и. мед.* Радий һәм башка радиоактив матдәләр белән дәвалау.

РАДИОТЕ'ХНИК I *с.* Радиотехникага бәйләнешле. *Радиотехник тикшеренүләр.*

РАДИОТЕ'ХНИК II *и.* Радиотехника белгече.

РАДИОТЕ'ХНИКА *и.* Югары ешлыклы электромагнитик тирбәнешләрне өйрәнә торган һәм аларны элемтә, навигация, астрономиядә һ. б. куллану юллары (методлары) турындагы фән. || *с. мәгъ.* Радиотехникага бәйләнешле.

РАДИОТРАНСЛЯ'ЦИЯ *и.* Элемтәнең чыбыклы линиясе ярдәмендә радиопрограммалар тапшыру. || *с. мәгъ. к.* радиотрансляцион. *Радиотрансляция челтәре.*

РАДИОТРАНСЛЯЦИОН *с.* Радиотрансляциягә бәйләнешле.

РАДИОТЫҢЛАУЧЫ *и.* Радиотапшыруларны тыңлаучы. *Радиотыңлаучылар соравы буенча төзелгән концерт.*

РАДИОУ'ЗЕЛ *и.* Чыбыклар аша радиопрограммаларны трансляцияләү, радиоэлемтә тоту һәм радиотапшырулар алып бару өчен махсус җиһазландырылган пункт. || Радиодулкыннар кабул итә һәм тарата торган учреждение. — *Тыңлагыз, „Таң“ колхозы радиоузелы тапшыруларын башлыйбыз.* А. Әхмәт.

РАДИОФИ'ЗИКА *и.* Физикада радиотехниканың физик нигезләрен, техниканың радиотехникага бәйләнешле тармакларын өйрәнә торган бер өлкә.

РАДИОФИКА'ЦИЯ *и. к.* радиолаштыру.

РАДИОХИ'МИЯ *и.* Радиоактив элементларның физик һәм химик үзлекләрен өйрәнә торган фән.

РАДИОЭЛЕКТРО'НИКА *и.* Радиотехникадан һәм электроникадан үсеп киткән фән тармакларының гомуми исеме.

РАДИОЭЛЕМТӘ *и.* Радио ярдәмендә башкарыла торган элемтә. *Радиоэлемтә мәсьәләсен тормышка ашыру өчен, Попов үзенең беренче башлап ясаган тәҗрибәләрендә, тапшыргыч прибор итеп, Герцның иң гади вибраторыннан файдаланган.* Физика.

РАДИОҖИҺАЗ *и.* Радио өчен кирәкле җиһаз (һәртөрле аппаратлар һ. б.).

РАДИСТ *и.* Радио аша хәбәрләр тапшыручы һәм кабул итүче белгеч. *Радист, тәрҗемәче һәм тагын өч разведчикны уятып, алга куелган бурычны аларга төшендердем.* Ә. Айдар. *Күрәсең, Татарстан җирләре якынлашкангадыр, үзелда утыручы радист татарча җыр уйната башлады.* А. Расих.

РА'ДИУС *и. мат.* **1.** Әйләнәнең яки шар өслегенең теләсә кайсы ноктасын үзәк белән тоташтыра торган туры сызык; шул туры сызыкның озынлыгы.

2. *күч.* Берәр нәрсәнең таралу өлкәсе, таралыш киңлеге, тәэсир яки хәрәкәт итү даирәсе. *Нефть промышленностеның специфик үзенчәлекләре бар. Аларның беренчесе — предприятиеләрнең бер-берсеннән ерак урнашуында.* [*Безнең идарәдә*] *операторлар хезмәт күрсәтә торган скважиналар радиусы бик зур.* Соц. Тат.

РАДОН *и.* Радиоактив химик элемент, радий таркалганда барлыкка килә торган газ. || *с. мәгъ.* Радонны куллану, файдалану белән бәйләнгән. *Радон ваннасы алу.*

РАЗВЕ'ДКА *и.* **1.** Берәр урынны тикшереп, өйрәнеп, анда нәрсәләр барлыгын, нәрсәләр эшләнүен һ. б. ларны ачыклау. *Сугышның өченче елында --- Кәлимәт якларыннан нефть эзләүче геологик разведка узды.* Г. Ахунов. *Безнең кызлар алтын эзләп Разведкага йөриләр.* Ә. Ерикәй. || *хәрби.* Дошман турында мәгълүматлар туплау максаты белән гаскәри часть, группа, подразделение, дозор һ. б. ш. тарафыннан аның территориясендә яшерен рәвештә алып барыла торган эш яки сугыш хәрәкәте. *Газетада разведканың уңышлы үтүе, шуның нәтиҗәсендә дошманның оборона серләре ачылып аның тар-мар ителүе турында язылган иде.* Ә. Айдар. *Укчы ротадан разведкага җибәрелгән Газинур отделениесенең бурычы һөҗүм алдыннан дошман оборонасының характерын ачыклау иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Дошман турында мәгълүматлар туплау эшен башкара торган гаскәри группа, подразделение һ. б. *Озакламый мине разведкадан күчерделәр, һәм без Дәүләтшин белән аерылыштык.* И. Гази. *Дивизиянең разведкасында татарлар булса да, бу кадәр моңлы, ягымлы итеп җырлаучыны мин белми идем.* Ә. Айдар.

3. Башка дәүләтләрнең экономик һәм политик хәле, хәрби көчләре һ. б. турында мәгълүматлар җыю белән шөгыльләнә торган оешма. *Агентура разведкасы.*

4. *с. мәгъ.* Разведкага бәйләнешле; разведка эше белән шөгыльләнә, разведка эшен башкара торган. *Разведка эшләре. Разведка отряды.* □*Кече лейтенант, үз землянкасына кайтып, разведка планын төзергә кереште.* Г. Әпсәләмов. *Оренбург ягыннан өч-дүрт вагонлы разведка поезды килде.* Ш. Усманов.

Разведка ясау — **1)** күзәтү ясау; эзләнү, тикшеренү, кызыксыну. *Фәннең төрле тармакларына разведка ясау.* □*Муса Җәлил катлаулы юллар белән үсеп бара. Ул әдәби мәктәпләргә разведка ясый, бик күп укый, өйрәнә.* Г. Кашшаф; **2)** *шаярт.* Аерым максат белән берәр нәрсәне, урынны тикшерү (тикшереп карау). — *Өстәл астыннан бер кастрюль эзләп таптым, --- кашык белән эченә разведка ясап алам: калҗасы шәп — бер кило булыр.* Г. Ахунов.

РАЗВЕДКАЧЫ *и. к.* разведчик. *Разведкачы бик тиз генә килеп честь бирде.* Ә. Исхак.

РАЗВЕ'ДЧИК *и.* **1.** Разведкада (2 мәгъ.) күзәтү эшен башкаручы хәрби хезмәткәр; разведкага (2 мәгъ.) җибәрелгән гаскәри. *Ярга чыгу белән тәрҗемәче разведчикны алга, разведкага җибәрдем.* Ә. Айдар. *Разведчиклар яшен тизлеге белән „тел“не күтәреп алып, куе караңгылык эченә кереп югалдылар.* А. Әхмәт.

2. Разведка (3 мәгъ.) агенты, эшчесе; разведка органнарында эшләүче. *Разведчик, үз тормышын һәрвакыт куркыныч астына куеп, дошман тылында яки тирәлегендә эшләргә тиеш.* Соц. Тат.

3. Җир асты байлыкларын, файдалы казылмаларны эзләүче белгеч. *Разведчик егетләр килгән, Җырны тыңлыйбыз дилəр.* Җыр.

РАЗВЁРСТКА *и.* Эш көчләрен, коралларны, продукцияне һ. б. планлы рәвештә бүлү. [*Авылда*] *иң элек разверстканы түләп бетерүче Сәмигыл абзый булды.* М. Гали. || Күрсәтмә, план, наряд. [*Иманенко:*] *Дүрт кешене Казанга укырга җибәрергә развёрстка бар.* һ. Такташ.

РАЗВОД *и. хәрби.* Постларга тарату алдыннан сакчыларның постта торырга әзерлекләрен тикшереп чыгу һәм аларга элеккеге сакчыларны алмаштырырга хокук бирү.

РАЗВОДЯ'ЩИЙ *и. хәрби.* Сакчыларны постларга таратучы хәрби хезмәткәр. — *Монда разводящий белән алмашчы часовой гына керергә тиеш.* Ә. Айдар.

РАЗМЕР *и.* Өс-баш һәм аяк киемнәренең күләм үлчәме, номеры. — *Ягез, иптәш, нинди размер пальтолар кирәк сезгә? — дип, сатучы ханым* [*Солтанның*] *татлы уйларын бүлде.* Г. Кутуй.

РАЗНАРЯ'ДКА *и. к.* наряд (1, 2. *мәгъ.*). [*Директор*] *вагон-складка завхоз --- янына разнарядка язарга керде.* И. Салахов.

РАЗНОЧИН *и. к.* разночинец. || *с. мәгъ.* Разночинецка бәйләнешле. *Разночин интеллигентлар. Разночин язучылар.*

РАЗНОЧИ'НЕЦ *и.* XVIII йөз ахырында һәм XIX йөздә Россиядә: дворяннардан башка катлаулардан — сәүдәгәрләр, руханилар, вак чиновниклар, мещаннар, крестьяннардан чыккан интеллигенция вәкиле. *Буржуа табигый рәвештә үз сыйныфы партиясенә керепкөрәшкән булса, вак буржуа интеллигентлары, разночинецларның күпчелеге демократик буржуа партияләрендә эшләделәр.* Г. Нигъмәти.

РАЗРЯД *и.* **1.** (Нинди дә булса профессиядә, белгечлектә, спортта һ. б.) квалификация дәрәҗәсе. *Леша дигән карт большевик кул астында эшлим. Күптән түгел, проба биреп, разряд алдым.* А. Расих. *Һәрбер милли совет спорт төре буенча разрядлар, мактаулы исемнәр булдырырга, дипломнар, мактау кәгазьләре тапшыруны тәртипкә китерергә иде.* Н. Фәттах.

2. *мат.* Санны язма рәвештә күрсәткәндә цифр биләгән урын. [*Тапкырлаган вакытта машинадагы махсус җайланма*] *бирелгән санны, тапкырлаучының барлык берәмлекләрен һәм нульләрен исәпкә алып,*

кирәк кадәр сандагы разрядка ялгышусыз-нисез шуыштыра. Уйлаучы машиналар.

3. *иск.* Үзара охшаш, уртак яклары булган кешеләр төркеме, теге яки бу яклары белән бер-берсенә охшаган әйберләр, күренешләр төркеме. *Ул елны алар авылыннан каралырга килгән егерме ике егеттән сигезен алдылар, калганнары кайсы яшелгә (өч елга), кайсы кызылга (бер ай барып өйрәнергә), кайсы зәңгәргә (икенче разряд ополчениегә) калдылар.* М. Гали. *Белешмәдә әйтелгәнчә,* [*Шидловский китапханәсендә*] *китап алып укучыларның беренче разряды 15 сум, икенче разряды 12 сум --- һәм бишенче разряды 6 сум акча түләргә тиеш булган.* Соц. Тат.

РАЗРЯ'ДКА *и. тип.* Хәрефләрне сирәкләтеп, араларын киңрәк калдырып җыю.

РАЗРЯДЛЫ *с.* Разряды булган. *Өченче разрядлы ресторан. Күп разрядлы саннар.* □ *— Слесарь дигәч тә, мин әллә нинди зур разрядлы слесарь түгел,— диде кыз.* А. Шамов.

РАЗЪЕЗД *и.* 1. *хәрби.* Зур булмаган атлы разведка яки атлы сакчылар подразделениесе (төп көчләрдән алда җибәрелә).

2. Тимер юлда: каршы килгән поездларны үткәреп җибәрү өчен икенче юл. *Авыл читендәге калкулыктан алдагы 31 нче разъезд күренә. Разъездда акларның поезды бар.* Ш. Усманов. || Поезд туктый торган разъездлы (2 мәгъ.) пункт. *Икенче көнне паровоз --- пассажирлар белән тулы булган озын составны Иртышның икенче ягындагы җиденче Авыл дигән бер разъездга китереп туктатты.* Н. Фәттах.

РАЗЫЙ *хәб. сүз. кит. к.* риза. *Авылны күпме мактасаң да, аның калада торып өйрәнгән кешене разый итмәслек урыннары табыла икән.* Г. Тукай. [*Гали Зөләйхага:*] *Үзеңне миңа бирергә атаң-анаң разый булмаган вакытта да син минем белән качарга разый идең.* Г. Коләхметов.

Разый булу — *к.* риза булу. *Хөррият өчен йөрүчеләр, хәзерге хөкүмәттән разый булмаган кешеләр һәр көнне төрмәләргә, крепостьларга тутырылалар, Сибириягә озатылалар.* Ш. Мөхәммәдев. **Разый түгел** — каршы килү, канәгать түгел. [*Анри Барбюсның „Елаучылар" җыентыгындагы шигырьләрендә*] *төп мотив — әйләнә-тирәдәге тормыштан бизү, хәзерге хәлләрдән разый түгеллек иде.* М. Җәлил.

РАЗЫЙЛАУ *ф. кит. к.* ризалату.— *Бу акчаларны мин сиңа Миңсылу өчен бирәм. --- Миңа ошый ул кыз. Әгәр мин сине разыйласам, ул миңа чыгарга каршы түгел.* Г. Минский.

РАЗЫЙЛЫК *и. кит. к.* ризалык. *Россиянең иске тәртибеннән разыйлык күрсәтә торган вәкилләр әүвәлге ике Думада сүзләрен үткәзә алмас дәрәҗәдә аз иделәр.* Ф. Әмирхан.

РАЗЫЙСЫЗЛЫК *и. кит. к.* ризасызлык. [*Анри Барбюсның*] *„Соранучылар" (1903) һәм „Тәмуг" (1908) атлы романнары да* [*әйләнә-тирәдәге тормыштан*] *разыйсызлык --- белән сугарылган иделәр.* М. Җәлил.

РАЙ- Кушма сүзләрдә район мәгънәсендәге беренче кисәк: мәсәлән: *райком, райбашкарма комитеты, раймаг.*

РАЙКОМ *и.* Район комитеты. *Райком секретаре.* □ *Комсомол райкомыннан килеп, комсомолга керергә теләүчеләргә анкеталар калдырып киттеләр.* Г. Гобәй.

РАЙОН *и.* 1. География, экономик һ. б. ш. билгеләр белән үзенә мөстәкыйль аерымланып торган төбәк, як. *Илнең көньяк районнары. Игенчелек районы.* □ [*Ирек:*] *Кайсы әйтә—Казанка елгасы белән өскә таба менәбез, ди. Кайсы Шөгергә, нефть районына, ди.* Д. Аппакова. || Халык яши торган урынның, төбәкнең нинди дә булса билгеләр белән аерылып торган өлеше. *Эшчеләр районы. Үзәк район.* || Нинди дә булса хәрәкәт бара торган, билгеле бер эш башкарыла торган урын. *Сугыш хәрәкәтләре барган район.*

2. СССРдагы өлкәләр, крайлар, республикалар, шулай ук зур шәһәрләр составына кергән административ-территориаль берәмлек. *Казанның Ленин районы.* □ *Гафиятулла абзый авыл халкының бер өлеше белән Бөгелмә районына күчәргә ризалыгын белдерә.* Г. Әпсәләмов. *Казан артистлары турындагы хәбәр бөтен районга таралып өлгергән.* Н. Фәттах. || *сөйл.* Шундый берәмлекнең административ үзәге; административ үзәктәге җитәкче оешмалар. *Тимербулат көн дә иртән Торып китә районга.* М. Җәлил. *Бераздан гармоньнар уйнатып районга киттек.* Ә. Айдар.

3. Нәрсәгә дә булса якын торган, берәр нәрсә тирәсендәге урын. *Вокзал районы.* □ *Яңа ел каршылау көннәренең берсендә шәһәр үзәгеннән завод районына баручы троллейбуска --- ике кеше менде.* Г. Минский.

РАЙОНАРА *с.* 1. Районнар арасында урнашкан, яшәп килә торган. *Районара ярыш. Районара әлемтә.*

2. Берничә район өчен уртак булган. *Камышлы Чирмешәннән ике тапкыр зуррак, --- интеллигенция дә монда күбрәк, шуның өстенә һәртөрле районара оешмалар да Камышлыда тупланган.* Ә. Еники.

РАЙОНДАШ *и.* Икенче берәү белән бер үк районда яшәүче. *Телеграммалар! --- Нинди телеграммалар дип ачса, райондашларыннан!* Г. Әпсәләмов.

РАЙОНЛАШТЫРУ *ф.* 1. Нинди дә булса территорияне административ, экономик һ. б. ш. районнарга бүлү. *Экономик районлаштыру --- производствоны илнең аерым районнары буенча планлы рәвештә территориаль урнаштыру ул.* Политэкономия.

2. Билгеле районга яраклаштыру, аның табигый шартларына җайлаштыру. *Бодайның сортын районлаштыру. Сыерларны токым буенча районлаштыру.*

РАЙОНЛАШУ *ф.* 1. Территориаль-административ, экономик һ. б. яклардан районнарга бүленү, районга әйләнү. *Районлашуга чаклы волость торган бу авыл яңадан корыла башлаган иде.* С. Рафиков.

2. Билгеле бер районга, аның табигый шартларына яраклашу, җайлашу.

РАЙҮЗӘК *и.* Район үзәге. *Райүзәкнең үзендә никадәр генә эш күп булмасын, төүлекнең билгвле бер вакыты буш кала.* Ә. Еники. — *Мин сезнең райүзәкне бу кадәр матур дип һич тә уйламаган идем.* А. Расих.

РАК *и. мед.* 1. Кешенең, хайваннарның эчке яки тышкы органнарында була торган дәвамлы авыру; яман шеш. *Ашказаны рагы.* □ — [*Якын киләчәктә*] *рак кебек --- чирләр дә җиңеләчәк.* Г. Әпсәләмов.

2. Үсемлек сабакларында һәм тамырларында тукымаларның тышкы яктан оры сыман зураеп үсеп китүе яки черүе нәтиҗәсендә барлыкка килә торган йогышлы авыру.

РАКЕ'ТА *и.* 1. Фейерверклар һәм хәрби эштә сигнал бирү яки яктырту өчен кулланыла торган янар патрон. *Шәһәр өстендә кызыл һәм яшел ракеталар күренде.* Ш. Хөсәенов. *Яктырткыч ракеталарның һавага сикергәннәре, минутлар буена эленеп торып, акрын гына, ашыкмый гына җиргә, караңгыга төшкәннәре күренә.* А. Шамов.

2. Реактив двигательле очу аппараты. *Космик ракета. Баллистик ракета.* || *хәрби.* Газ агымы тәэсире белән хәрәкәткә китерелә торган сугыш снаряды. *Яндыргыч ракеталар.*

Ракета йөрткеч — күп буынлы ракетаның Җир яки Кояш ясалма иярченнәрен һәм иярчен космик кораблъләрне орбитага чыгару өчен хезмәт итә торган соңгы буыны.

РАКЕ'ТАЛЫ *с.* Ракеталар җибәрү өчен билгеләнгән. *Ракеталы двигатель атмосферада да, һавасыз бушлыкта да эшли.* Күкне штурмлау.

РАКЕ'ТКА *и. спорт.* Теннис уйнау өчен челтәрле калак, чәпәмә.

РАКЕ'ТАЧЫ *и.* 1. Ракета белән сигнал бирүче.

2. *хәрби.* Ракета гаскәрендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәр. *Галимнәрне, очучыларны, ракетачыларны җыйганнар да оча торган серле тәлинкәләр турында сөйләшкәннәр.* А. Гыйләҗев.

РАКЕ'ТНИЦА *и.* Сигнал ракеталарын җибәрү өчен махсус җайланма. || Ракета (1 мәгъ.) ату өчен махсус пистолет. *Ике немецның берсе ракетницадан як-якка шарт-шорт ата бара, аның артыннан күкле-яшелле, кызыллы-зәңгәрле ут чәчәкләр чәчелеп кала иде.* Ш. Маннур.

РАКЕТОДРОМ *и.* Ракеталар (2 мәгъ.) җибәрү һәм сынау өчен җиһазландырылган махсус мәйдан.

РА'КОВИНА *и.* Су краны астына юыну өчен куелган бүрәнкә сыман җайланма. *Диләфрүз, суны раковинага түгеп, усалланып киткән күзләре белән иңбашы аша ишеккә карап торды.* Г. Әпсәләмов.

РАКУ'РС *и.* 1. Сурәтләнә торган фигураны яки әйберне перспективада биргәндә, аның арткы пландагы өлешләренең кечерәйтелгән булуы. *Ракурс белән төшерү.*

2. *махс.* Яктылык сизүчән фотоматериал катлавының әйбер урнаштырылган яссылыкка параллель булмавы аркасында әйбернең сурәтләнешендә барлыкка килгән, күрер күзгә гадәти булмаган перспектива.

3. Нәрсәнең дә булса берәр төрле ягы, күренеше. [*Идрис*] *бу дөньяны тискәре яктан, моңарчы бер чакта да күтәрелеп карамаган яңа ракурста күрде.* А. Гыйләҗев. [*Врач*] *төрле ракурста төшерелгән снимокларны күрсәтә-күрсәтә сөйләде.* Ф. Яруллин.

РАМ *и.* 1. Эченә картина, көзге, портрет кебек әйберләр кую өчен борыслардан, планкалардан гадәттә дүрт почмаклап яки башкача ясалган җайланма; кыса. *Көзге рамы. Картина рамы. Рамга кую.* □ *Стенада — пыяла рам эчендә төрле фоторәсемнәр.* А. Әхмәт. *Егермеләп тәрәзә рамын яңадан ясарга --- кирәк.* М. Гали. || Умартада бал кәрәзе өчен дүртпочмаклап ясалган агач кыса. *Рамнардан бал суырту.* □ *Рамнарның әле тирән күзәнәкле кәрәзләре юк.* А. Алиш.

2. *махс.* Машинаның, нинди дә булса корылмаларның яки җайланмаларның аерым частьлары куелган нигез өлеше. *Автомобиль рамы. Вагон рамы. Пычкы рамы.* □ *Трактор рамнарын ремонтлау бригадасы - - - һәр көнне 2 рам ремонтлап чыгара.* Соц. Тат.

РАМАЗАН *и. иск.* Мөселманнарда: айның җир тирәли хәрәкәтенә карап ел исәпләү календаренда тугызынчы ай; ураза ае. *Оренбург муллалары үткән рамазанда, руза тотмаган кешеләрне тотып ябарга ярдәм итешер өчен, полициядән городовойлар сораганнар.* Г. Тукай.— *Ни күзем белән күрим: бер чикылдаган татар хәлфәсе рамазанда көндез ашап, чәй эчеп утыра.* Ф. Әмирхан.

РА'МКА *и.* 1. Кечкенә рам (1 мәгъ.). — *Дә карагыз,— [Әбүзәр] кайчандыр Гөлшаһидәнең рәсеме торган буш рамкага күрсәтте.— Юкка чыкты бит.* Г. Әпсәләмов. || Нинди дә булса текстны, рәсемне, бизәкне әйләндереп алган график кыса. *Татарча театр уйналганнан бирле „Бәянелхак“ кайгыда — кара рамкада чыга башлады.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *күч.* Кем тарафыннан да булса билгеләнгән яки гомуми кабул ителгән шартлы чикләүләр. [*Зыяның*] *эчендәге „музыка дөньясы, музыкадан лаззәт алу өчен яратылган тойгылары“ күп елларгача, шәкерт вә мәдрәсә галәменең куәтле рамкалары эченә кысылып, әллә кайда, төптә, рухның әллә нинди эчке катлауларында бикләнеп ятарга мәҗбүр булалар.* Г. Ибраһимов. *Дисциплина рамкасыннан чыкмаган биш-алты йөз кешелек отряд, сугышның барышын үзгәртә алмаса да, вокзалны бушатуда зур роль уйнады.* Ш. Усманов.

РА'МКАЛАУ *ф.* Рамкага (1 мәгъ.) кую, рамка эченә кую. *Фоторәсемне рамкалау.*

РА'МКАЛЫ *с.* Рамкага куелган, рамкада булган. *Өй җиһазлары иске заман нәрсәләре белән кара-катыш, стенада рамкалы язулар.* Г. Камал.

РАМЛАУ *ф.* Рамга (1 мәгъ.) кую, рам эченә кую. *Портретны рамлау.* || *махс.* Рамнар кую (мәсәлән, тәрәзәләргә). *Тәрәзәләрне рамлау.*

РАМЛЫ *с.* Рам (1 мәгъ.) эченә куелган, рамланган. *Рамлы картина.* || Рам (2 мәгъ.) өстенә куелган. *Рамлы тракторларның механизмнарын көйләү һәм төзәтү җиңелрәк.*

Рамлы антенна — рам, кыса формасындагы антенна.

РАМЛЫК *с.* 1. Рам (1 мәгъ.) ясау өчен билгеләнгән. *Рамлык агач.* || Рам (1 мәгъ.) ясарга җитәрлек булган. *Бер рамлык агач.*

2. *и. мәгъ.* Рам ясау өчен билгеләнгән материал. *Рамлык сатып алу.*

РА'МПА *и. театр.* Сәхнәне яктырту өчен сәхнә алдына тезелгән лампаларны каплап торган барьер. [*Артист*] *ике кулын күкрәк өстендә кушырып, башын кыйшайта. төшеп, рампа янына ук килеп басты.* Г. Әпсәләмов. || Шундый барьер артына урнаштырылган һәм сәхнәнең алгы ягын түбәннән яктырта торган аппаратура. *Әмма бу алкыш, бу күз камаштыргыч рампа уты [Хәбирнең] бөтен өйрәнгәннәрен башыннан чыгарды.* Ш. Хөсәенов.

РАМЧЫ *и.* 1. Рам (1 мәгъ.) ясау, кую белән шөгыльләнүче оста.

2. Пычкы рамында эшләүче эшче.

РАНГ *и.* 1. Дәрәҗә, махсус исем; чин. *Икенче ранг капитан. Дипломатик ранглар.* □ *Күчергәләп рәт чыкмагач, Калмагач бернинди ранг, Үзебезгә кайтып төштә, әйтерсең бумеранг.* Ш. Галиев. *Ул үзе Совет Армиясендә өченче ранг хәрби юрист булып хезмәт иткән.* Г. Кашшаф.

2. *махс.* Сугыш судносы категориясе разряды. *Беренче ранг крейсер.*

РАНГО'УТ *и. махс.* Җилкәннәрне күтәрү, киерү, тотып тору һәм төшерү, шулай ук сигналлар бирү, йөк күтәрү җайланмаларын урнаштыру һ. б. өчен хезмәт итә торган судно корылмаларының (мачта, стеньга, рея һ. б. ларның) җыелмасы.

РАНЕТ, РЕНЕТ *и.* Кышкы сорт алмаларның бер төре.

РА'НЕЦ *и.* Аркага асып йөртә торган поход сумкасы яки китап букчасы. *Бераздан соң җигүле ике ат килеп туктады. Берсенә конвойчыларның шинель, ранец, азык-төлек шикелле нәрсәләре төялгән.* Ш. Маннур.

РАНЖИР *и. иск.* 1. Кешеләрнең буйларына карап сафка тезелүе.

2. *күч.* Нәрсәдә дә булса билгеле бер тәртипнең

булуы, барлыгы. *Ранжир саклау.* □ *Син тезәсең безне бер сафка, Шигъри казанышлар ранжирында Иң танылган ирләр — Уң якка!* С. Баттал.

РАНТ *и.* Аяк киеменең өске өлешен тышкы яктан олтан белән тоташтырып теккән тар күн кайма.

РАНТЛАУ *ф.* Рант ясау, рант белән тегү (мәсәлән, ботинканы).

РАНТЛЫ *с.* Рант белән тегелгән (мәсәлән, аяк киеме).

РАНТЬЕ *и.* Капиталистик җәмгыятьтә: кыйммәтле кәгазьләргә-акцияләргә, облигацияләргә салынган капиталдан килә торган доход хисабына эшләмичә яшәүче кеше. *Империализм эпохасында буржуазиянең күпчелек өлеше рантьега әверелә.* Яңа тарих. || *с. мәгъ.* Рантьега бәйләнешле; рантье булып торган. *Рантье катлавының производстводан тулысынча аерылуы капитал чыгару, чит илләргә салган капиталдан килгән керемнәр белән тагын да көчәя.* Политэкономия.

РАПА *и. махс.* Тозлы күлләрдә тоз белән туендырылган су (дәвалау өчен кулланыла). *Әгәр бер литр суда бер грамм калдык булса, андый суны тозсыз гади су диләр, 50 граммнан артса, бик нык тозланган яки рапа дип йөртәләр.* Җир һәм туфрак.

РАПИ'РА *и. спорт.* Фехтование уенында чәнчү өчен кулланыла торган озын һәм сыгылмалы дүртқырлы корал. *Совет спортчылары - - - рапирада дөнья беренчелегенә үткәрелгән команда ярышларында җиңеп чыктылар.* Соц. Тат.

РАПИ'РАЧЫ *и.* Рапира спортчысы. *Совет рапирачылары командасы.*

РА'ПОРТ *и.* Эшнең торышы, эш урынындагы хәл һ. б. ш. турында телдән яки язма рәвештә югары инстанциягә, эш башында торучыларга бирелгән рәсми доклад, мәгълүмат. *Баш инженер исеменә язылган рапортлардан соң, шактый вакыт тәртипле генә йөргән [Кукушкин] тагы да килеп абынды.* С. Рафиков. *Илсөяр рота командирына рапорт биреп торган зур гәүдәле кешенең оялып кына белгеннән тотты.* Г. Гобәй. || Алынган йөкләмәләрнең үтәлеше турында доклад, хәбәр. *Нинди кояш миңа җылы бирер, Якын күреп миңа кем дәшәр, Иң зур кояш булган дәүләтемә Җиңү белән рапорт бирмәсәм.* М. Җәлил.

РАПСОД *и.* Борынгы Грециядә: халык җырларын җыючы, эпик поэмалар башкаручы илгизәр җырчы, нәфис сүз остасы.

РАПСО'ДИЯ *и.* 1. Борынгы Грециядә: рапсод башкара торган эпик әсәрдән өзек.

2. Халык җырлары, биюләре темасына язылган зур күләмле инструменталь яки вокаль-инструменталь музыкаль әсәр. *Венгр рапсодиясе.* □ *Мин - - - туган җирем, халкым тормышыннан бер кыйтга — рапсодия язарга телим.* Ә. Баян.

РАС *с. сөйл.* 1. Дөрес, чын, хак. *Рас хәбәр.* □ *Рас сүзгә җавап юк.* Мәкаль.

2. *рәв. мәгъ.* Дөрес, чынбарлыктагыча; урынлы. *Рас әйттең син, туган, сүзеңне.* Н. Исәнбәт. || Нәкъ, шулай, шиксез. *Эш рас мин әйткәнчә килеп чыкты.* || *хәб. сүз. функ.* Дөрес, чын, хак; хаклы, урынлы; шиксез. [*Исмәгыйль:*] *Сезнең тирәдә козгыннар йөри диләр. Расмы әллә шул сүз?* М. Фәйзи. *Байның шикләнүе рас икән, бу адәм сарманнардан найманнарга сер ташый икән дип уйладым.* Г. Ибраһимов.

Рас килү — 1) тап булу, туры килү, очрау, юлыгу, юллар берләшү. [*Хәсән:*] *Күрдегезме безнең бикәне! Шәпме? Менә дөнья көт инде бу җанлы курчак белән! И, үзең сакла шундый ваемсыз, фикерсез хатынга рас китерүдән.* Ш. Мөхәммәдев. 2) нәкъ үзенә, үзәгенә тап булу (туры килү). *Һаваны сызгырып ярып, тал чыбык тегенең йөзенә рас килде, күрәсең.* Г. Минский. 3) дөрескә, чынга чыгу, чынбарлыкта дөресләнү, тормышка ашу (әйткән сүз, план, төш һ. б.). **Раска килү (чыгу)** — *к.* рас килү (3 мәгъ.). *Бикмүш бабайның шиге раска килде. Икенче көнне үк будка тирәсендә сәер „балыкчылар" күренә башлады.* Г. Гобәй. *Ул - - - шаярып әйтелгән сүзләренең раска чыгып куюыннан курка.* Х. Кәрим.

РА'СА *и.* 1. Килеп чыгышлары һәм бит, тән төзелеше, күз формасы, тире һәм чәч төсе һ. б. ш. кайбер нәсел үзенчәлекләрендәге гомумилек белән берләшеп, тарихи формалашкан кешеләр төркеме. *Кешелек дөньясы берничә расага бүленә.* Биология.

2. *к.* расачылык. *Анда поскан фашист бүреләре Яшереп йөртә бездән планын. Тик шулай да безгә ул сер мәгълүм: Башларында раса томаны.* Н. Исәнбәт.

РА'САЧЫ *и.* Расачылык тарафдары.

РА'САЧЫЛЫК *и.* Төрле расалар үзара тигез түгел, аларның акыл сәләтләре табигать тарафыннан тигез билгеләнмәгән һәм культура үсеше ягыннан да сәләте тигез дәрәҗәдә түгел дигән фикерне алга сөреп, кешелек дөньясын „югары" һәм „түбән" расаларга бүлеп, „югары" раса „түбән" раса өстеннән хакимлек итәргә тиеш дип дәгъвалый торган буржуаз теория, реакцион политика. || *с. мәгъ.* Расачылыкка бәйләнешле; расачылыкны алга сөрә торган, яклаган. *Расачылык теориясе.*

РАСИЗМ *и. к.* расачылык.

РАСИСТ *и. к.* расачы.

РАСКЛАДУ'ШКА *и. сөйл.* Җиңел җыелма карават. *Мансурның бүлмәсендә исә бер раскладушка, бер өстәл, ике-өч урындык һәм ящик өстенә куйган радиоалгычтан башка берни дә юк иде.* Г. Әпсәләмов.

РАСКОЛ *и.* Фикер каршылыклары нигезендә кемнең яки нәрсәнең дә булса ике яки берничә группага, өлешкә бүленүе. *Троцкийчылар һәм зиновьевчылар Коминтернда раскол ясау юлына бастылар.* КПСС тарихы.

РАСКОЛЧЫ *и.* Нинди дә булса оешмада раскол тудыручы, раскол ясарга котыртучы.

РАСКОЛЧЫЛЫК *и.* Нинди дә булса оешмада раскол ясауны максат итүче, шуңа булышлык итүче. *Расколчылык тактикасы.*

РАСЛАМА *и.* Раслаучы (исбатлаучы, дәлилләүче, дөресләүче) факт; билгеләүче факт.

РАСЛАУ *ф.* 1. Исбатлау, дөресләү. *Театр исеменә алынган йөзләрчә телеграммалар, бу бәйрәмнең Татарстан кырларында гына чикләнмичә, бөтен Советлар Союзы халкы бәйрәменә әйләнгәнен раслады-лар.* М. Җәлил. *Зур җиңешләр белән раслый Гаскәр минем сүземне.* Ф. Бурнаш. || Дөресләү, дөреслегенә ышаныч белдерү. *Картлар аның сүзләрен раслап, башларын селкештергәләп алалар һәм ялгыз ижектән торган ниндидер сүз әйтеп куялар.* А. Шамов. || Гамәлгә ашыру. [*Гетман*] *без ул патшаның көчле кулы астында ныгырбыз [диде]. Барлык халык бердәм рәвештә: ярабби, үзең расла, ярабби, дуслыкны ныгыт, гомер-гомергә берләшеп яшәсәк иде,— дип ялварды [Украинаның рус дәүләтенә кушылуы турында].* СССР тарихы.

2. Рәсми рәвештә хәл итү, карар кабул итү. *Җыелышның көн тәртибен раслау.* □ *— Казаннан кайткач, авыл коммунистларын җыярбыз: киңәшербез, планны расларбыз.* И. Гази. || Юридик рәвештә, закон тәртибендә рәсмиләштерү. *Милекка хокукны раслау.* || Кабул ителгән рәсми карарларны закон көченә кертү. *Верховный Совет карарын раслау.*

РАСЛЫК *и.* Хакыйкать, дөреслек, чынлык, хаклык; рас булу, дөрес булу, чын эш булу. *Озак та үтми-*

чә, мин частька кердем, Төшемнең раслыгын шул чакта белдем. Г. Тукай. *Сыртлановның башына килгән иң беренче уй --- раслыгына әле һаман да төшенеп җитмәгән нәрсәнең хыялмы, чынмы икәнлеген белү булды.* Ш. Хөсәенов.

РАСПИСА'НИЕ *и.* Нинди дә булса эшнең үтәлү вакыты, урыны, аның үтәлеш эзлеклелеге турында мәгълүмат бирә торган график, таблица. *Илебезнең тимер юлларында яңа расписание кертелде.* Соц. Тат. *Заһид тиз генә өстәл пыяласы астында ятkан дәреслəр расписаниесенә күз атты.* А. Расих.

РАСПИ'СКА *и.* Берәр нәрсә алганлыкны раслап кул куелган рәсми язу, документ. [*Ксения*] *кесәсеннән төенчек чыгарып, өстәлгә чишеп җибәрде. Аннан байтак кына көмешләр, бакырлар һәм берничә кәгазь акча килеп чыкты.— Санап ал да расписка яз!* К. Нәҗми. [*Рәхим*] *блокнотыннан бер бит кәгазь ертып алды да, профессор өстәле янына утырып, расписка язды.* А. Расих.

РАССО'ЛЬНИК *и. махс.* Тозлы кыяр салып пешерелгән итле аш яки балык ашы. *Рассольникка, яшел щига, кузгалак һәм шпинат ашларына томат салынмый.* Йорт эшләре.

РАСТРА'ТА *и.* 1. Дәүләт акчасын яки байлыгын законсыз рәвештә үзенең шәхси файдасына тоту, туздыру. *Растрата ясау.*

2. Шулай туздырылган дәүләт акчасы, дәүләт байлыгы; өстенә чыккан сума. *Растратаны түләү.* □ *Вак-төяк растрата, җитмәүчелекләр генә* [*Зөфәрне*] *куркытмый.* Ә. Еники.

РАСХОД *и.* 1. Тотылган яки тотылачак акча; чыгым. *Һәркемнең аерым-аерым язылган расходына карап, табышны Гариф өләште.* Ш. Камал. || Гомумән тотылган чыгым (продукт, ягулык һ. б.). *Ягулык расходы дизельләрдә (карбюраторлы двигательләргә караганда) 30—35 процентка кимрәк.* Тракторлар.

2. Бухгалтерия кенәгәләрендә чыгымнар языла торган бүлек, графа. *Расходка язу.*

Расход каплау — расходны түләү (кайтару). **Расход(ын) күтәрү** — расход каплауны үз өстенә алу, расходларны үзе түләү. — *Менә нәрсә, бабай, — диде егет яңадан сүзен дәвам иттереп,— ул терелеп аякка басканчы сезгә аның бөтен расходын күтәрергә туры килер.* А. Шамов. **Расход чыгару (ясау)** — акча һ. б. тоту. [*Искәндәр*] *өчен никадәр расходлар чыгарып тырышып ятабыз.* М. Фәйзи. **Расходка чыгару (җибәрү)** — 1) тоту, куллану, сарыф итү, файдалану. 2) *күч.* асу, кисү, атып үтерү. **Расходка чыгу** — тотылу, кулланылу, сарыф ителү. *Диссимиляция нәтиҗәсендә тәндәге матдәләр җимерелә һәм аларда тупланган энергия расходка чыга.* Анатомия.

РАСХОДЛАНУ *ф.* Расход, чыгым ясау. — *Дөресен әйтергә кирәк, минем хәзер кесәмдә бер тиен дә акчам юк. Сине дә расходландырасым килми.* К. Тинчурин.

РАСХОДЛЫ *с.* Чыгымлы, зур чыгымнар таләп иткән. *Зур расходлы мәҗлес.*

РАСЧЁТ *и.* 1. Хезмәт өчен түләү; акча заемнары, алыш-биреш һ. б. ш. буенча түләү.

2. Эш хакын түләп, эштән чыгару, азат итү. *Расчеттан соң, иртәгә китәсе дигән көнне, иптәшләр белән бераз төшердек тә урамга чыгып киттек.* Ф. Хөсни.

3. *сөйл.* Араны өзү, исәп-хисапны өзү. [*Шәйхулла әхмәткә:*] *Әнә, бер корчаңгы биям бар. Шуны ал... Дүрт ягың кыйбла: чабатаңны кыстыр да теләсәң кая кит. Шуның белән расчет.* Д. Аппакова.

4. *сөйл.* Файда, табыш күзлегеннән карап эш итү. *Расчет белән генә эш итү.* □ *Мин хәзерге кебек тиле сөяк һәм акыллы расчет капчыгы түгел идем.* Ф. Хөсни.

5. *хәрби.* Берәр сугыш коралына — пулеметка, тупка, минометка һ. б. хезмәт күрсәтүче гаскәриләр төркеме. *Пулемет расчетларын утка тоту.* □ *Расчетында эшләр ничек, Гафиятуллин? Матчастьны, тактиканы яхшы өйрәнәсезме?* Г. Әпсәләмов.

6. *техн.* Берәр корылманың проектын төзү өчен кирәк булган санлы мәгълүматларны исәплəп чыгару; хисаплама. — *Мин инде кайбер расчетлар ясадым, менә алар, — диде* [*Алмаев*], *кулындагы яшел блокнотын күрсәтте.* И. Гази.

7. *с. мәгъ.* Түләүгә, акча расчетына бәйләнешле. *Расчет кассасы.* □ *Банклар расчет үзәкләре ролен уйныйлар.* Политэкономия. || Исәп-хисап ясалган; эш хакы буенча түләүләр язылган. *Расчет кенәгәсе. Расчет исемлеге.* || *махс.* Расчет ясала торган, йомгаклый торган (квартал, ай). *Расчет ае. Расчет вакыты.*

Расчет алу — эш хакын алып, шушы эшкә бәйләнешле исәп-хисапны өзеп, эштән чыгу. *Булат шулай уйлады да китте шуннан районга: Артык хатлар ташымаска, эштән расчет алырга.* М. Җәлил. **Расчет бирү** — эш хакын түләп, эшкә бәйләнешле исәп-хисапны бетереп, эштән чыгару, эштән азат итү. [*Габделхәй:*] *Гәрәй аңа расчет бирә икән, аның бер дә исе китми, менә дигән забойщик ич ул. Теләсә кайда аны эшкә алалар.* Ш. Камал. **Расчет ясау** — 1) акча, бурыч мәсьәләсендә исәпләшү, исәп-хисап ясау. 2) *күч. сөйл.* Үзара мөнәсәбәтләрне өзү.

РАТИН *и.* Тышкы өс киеме өчен уң ягы төксел йон тукыма. || *с. мәгъ.* Ратиннан тегелгән. *Ратин пальто.*

РАТИФИКА'ЦИЯ *и.* Халыкара договорны югары дәүләт власте тарафыннан раслау. *Үзара сәүдә итү договорына ратификация.*

РАТИФИКА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Ратификация ясау. *Сәүдә договорын ратификацияләү.* □ [*IV Бөтенроссия съезды*] *Брест солых договорын ратификацияләде.* КПСС тарихы.

РА'ТУША *и.* 1. *тар.* XVIII йөздә һәм XIX йөз башында Россиядә шәһәр үзидарәсе органы; шул идарә урнашкан бина. [*Рәхмәтулла Дмирхан*] *озак еллар татар ратушасында тылмач булып эшли.* И. Рәмиев.

2. Кайбер Европа илләрендә шәһәр үзидарәсе урнашкан бина. [*Германиядә баш күтәрүче әсирләр*] *иске һәм яңа ратушаны, почтамтны, Эчке эшләр министрлыгын --- үз кулларына алырга тиеш булалар.* С. Шакир.

РАУЗА *и. иск.* 1. Гөл бакчасы.

2. *миф.* Җәннәт исеме, җәннәт бакчасы. *Я ходай! Нишлим, әгәр күрсәм кешенең зәүҗәсен? Торса ул яд иттереп җәннәт сарае раузасын?* Г. Тукай.

3. Бүлек, бүлекчә (китапта). *Беренче рауза. Икенче рауза.*

РА'УНД *и. спорт.* Бокс ярышында бер алышу дәвамы (гадәттә өч минут). *Мансур никадәр генә тырышмасын, иптәше аны беренче раундта ук дөмбәсләп ташлады.* Г. Әпсәләмов.

РАУШАН *с. иск.* Якты; ачык; саф, чиста, пакь, керсез; асыл. *Раушан йолдыз күптән балкый, Булатым юк — бу ни хәл.* К. Тинчурин. || Балкый торган, балкып тора торган. *Сәгатьләр үтте ай-еллар булып, Раушандай йөзең күрә алмыйча.* К. Тинчурин.

РАФИНАД *и.* Чистартылган шакмаклы шикәр. || *с. мәгъ.* Шуңа бәйләнешле. *Рафинад шикәр. Рафинад заводы.*

РАХИТ *и.* 1. Бала организмында известь тозлары җитмәү һәм матдәләр алмашуы бозылу сәбәпле сөякләрнең йомшак, зәгыйфь, тигезсез үсүеннән гыйбарәт авыру. *Рахит белән авыру.*

2. Рахит авырулы бала.

РАХИ'ТИК *и. к.* рахит 2. *Рахитикларда еш кына кан азлык авыруы була, йогышлы авыруларга каршы тору сәләте кими.* Анатомия.

РАЦИОН *и.* Билгеле бер срокка исәпләнгән азык порциясе һәм составы; билгеле бер вакытка җитәрлек паек. *Көнлек рацион.* □ *Яшь вакытта азык рационы мулрак булырга тиеш.* Анатомия. || Терлекләр өчен көнлек азык нормасы һәм составы. *Тавыкларга азыкны мин күрсәткән рацион буенча гына бирәбез.* Ә. Айдар. *Фәйрүзәнең бер сыеры да биш килограммнан артык сөт бирми, ә рацион барысына да бер бит.* Г. Бакиров.

РАЦИОНАЛИЗА'ТОР *и.* Җитештерүгә, җитештерү процессына рационализация кертүче алдынгы эшче (инженер һ. б.). [*Никитин:*] *Мин бу урында диапазоннары киңәя барган, мөмкинлекләре үсә барган рационализаторларыбыз турында җылы сүзләр әйтергә телим.* М. Хәсәнов.

РАЦИОНАЛИЗА'ТОРЛЫК *и.* Рационализатор(лар) эшчәнлеге; рационализация кертү эше. || *с. мәгъ.* Рационализаторлыкка бәйләнешле. [*Тәһир:*] *Минем рационализаторлык тәкъдимемне тикшерделәр.* Т. Гыйззәт. *Төшеп калганнардан түгел иде Баязит абзагыз. Заманасында уйлап тапкан чаклары да булгалады, рационализаторлык тәкъдимнәре дә керткәләде.* Ф. Хөсни.

РАЦИОНАЛИЗА'ЦИЯ *и.* Эшне аеруча файдалы, нәтиҗәле һәм максатлы итеп оештыру; эшне, эшчәнлекне яхшырту, тизләтү, камилләштерү.

РАЦИОНАЛИЗМ *и. филос.* 1. Кеше акылы чиктән тыш көчле, чынбарлыкны тулысынча танып белеп була дигән фәлсәфи караш.

2. Фикерләүнең тормыш тәжрибәсенә бәйләнешен инкяр итеп, дөньяны танып белүнең бердәнбер чыганагы акыл дип санаучы идеалистик философик юнәлеш. *Рационализм фәлсәфәсе күзлегеннән караү.*

3. *күч.* Тормышта акыл белән, уйлап эш итү.

РАЦИОНАЛИСТ *и.* 1. Рационализм (2 мәгъ.) тарафдары.

2. Тормышта акыл белән, уйлап эш итүче.

РАЦИОНАЛИ'СТИК *с. кит.* 1. Рационализмга (2 мәгъ.) нигезләнгән, рационализмга (2 мәгъ.) бәйләнешле. *Рационалистик философия.*

2. Акылга нигезләнгән, фәкать акыл таләпләренә генә таянган. *Рационалистик фикерләү.*

РАЦИОНАЛЛАШТЫРУ *ф.* Рационализация кертү. *Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә, җитештерүне рационаллаштырырга --- кирәк иде.* КПСС тарихы. *Рационаллаштыру һәм уйлап табучылык өлкәсендә йөкләмәләр арттырып үтәлә икән, бу әле барысы да эшләнеп бара дигән сүз түгел.* Каз. утл.

РАЦИОНАЛЬ *с.* 1. Рационализмга (2 мәгъ.) бәйләнешле.

2. Акылга ятышлы; төпле, нигезле; максатлы, нәтиҗәле, файдалы, урынлы. || *рәв. мәгъ.* Акыл белән эш итеп, уйлап; төпле (нигезле) итеп; нәтиҗәле итеп. *Терлек симертүне рациональ оештыру.* □ *— Армиядә мине рациональрәк файдаланып булмыймыни?* М. Җәлил.

3. *мат.* Бөтен сан белән яки бөтеннең өлеше белән үлчәп була торган; *киресе:* иррациональ. *Рациональ саннар берәмлек белән үлчәнешле булган зурлыкларның үлчәүлеге булып хезмәт итәләр.* Алгебра. || Тамыр алу билгесе, радикалы булмаган (алгебраик аңлатма). *Рациональ аңлатма.*

РА'ЦИЯ *и.* Күчмә радиостанция. *Без часовня территориясеннән рация аркылы беренче донесениене тапшырырга һәм яңа задание алырга тиешбез.* Г. Минский. *Мондый якын арада рация кулланып та булмый, дошман тотып ала һәм „чөй" суга башлый.* Ш. Маннур.

РАШКЫ *и.* Ап-ак төстә, бозга охшаш бик вак ярма сыман кар. *Каз авызын шакылдатса, рашкы явар.* Сынамыш. *Тургайга яңгыр тисә, баласын яшерә, рашкы тисә, үз башын яшерә.* Мәкаль.

РА'ШПИЛЬ *и.* Эре сырлы игәү.

РАШТУА *и. дини.* Христианнарның декабрь ахырында үткәрелә торган дини бәйрәме — рождество. *Раштуа җитте.* □ *Раштуада бер көрәк кар бирмәс.* Әйтем. || *с. мәгъ.* Раштуага бәйләнешле, раштуага караган.

Раштуа салкыннары (суыклары) — раштуа бәйрәме көннәренә туры килә торган кышкы каты салкыннар. *Раштуа суыклары җитте. Кыш суыкларына буйсыну — шуңа көйләнү чоры башланды.* Ә. Фәйзи. *— Хәбибрахман духтыр заманында [мичне] раштуа салкыннарында да икешәр көн якмый торган идек.* Г. Әпсәләмов.

РАҺИБ *и. иск.* Монах. *Картлач кардиналлар, епископлар --- Чекрәйгән күзле раһиблар --- Иңрәшәләр шунда, сызланалар, Советларга һәлакәт теләп.* М. Гафури.

РЕ *и.* Музыка гаммасында икенче тавыш („до"дан соң килә), шул тавышны белдерә торган нота.

РЕАБИЛИТА'ЦИЯ *и.* Ялгыш яки явыз ният белән яла ягылган, гаепләнгән кешенең намуслы исемен (абруен) кире кайтару, аклау. *Реабилитация ясау.* □ *Әтиегезнең реабилитация эшен мин алып барган идем... Яхшы кеше булган ул, гадел кеше!* А. Гыйләҗев. *— Шактый гына вакыт мин республика реабилитация комиссиясендә эшләгән идем.* Р. Төхфәтуллин.

РЕАБИЛИТАЦИЯЛӘНҮ *ф.* Реабилитация ясалу. *— Мин илле алтынчы елны реабилитацияләнеп кайткында хатыным үлгән иде инде.* А. Расих.

РЕАБИЛИТАЦИЯЛӘҮ *ф.* Реабилитация ясау.

РЕАГЕНТ *и. хим.* Химик реакциядә катнаша торган матдә.— *Хәзер мин сезгә торф реагенты ясап күрсәтәм.* И. Гази.

РЕАГИРЛАУ *ф.* 1. *физиол., биол.* Тышкы һәм эчке тәэсирләргә җавап бирү; шул күренешләрнең тәэсиренә бирелү (яраклашу, җайлашу). *Үсемлекләр җир тартымы юнәлешенә дә реагирлыйлар. Тау битендә үсә торган агачларга игътибар итегез. Җир өсте авыш булса да, агачлар вертикаль үсәләр.* Биология.

2. *хим.* Химик реакциягә керү, химик реакциягә катнашу. *Хлорид кислотасының нигезләр белән үзара реагирлавы аның бик әһәмиятле химик үзлеге.* Химия.

РЕАГИРЛАШУ *ф. хим. к.* реагирлау 2. *Натрий белән хлорид кислотасы аеруча көчле реагирлаша.* Химия.

РЕАКТИВ 1 *и. хим.* Берәр составка кушылгач, билгеле бер реакция ясый һәм шул состав эченнән эзләнелә торган икенче бер матдәне табарга яки аның юклыгын билгеләргә мөмкинлек бирә торган матдә. *Реактивлар хәзерләү.* □ *—Бу көннәрдә мин органик кислоталар белән маташтым. --- Хатыйп Закировичка рәхмәт, миңа методикасын бирде, реактивларын да кызганмый.* А. Расих. || *с. мәгъ.* Химик ана-

лиз вакытында реактив булып хезмәт итә торган. *Реактив матдәләр.*

РЕАКТИВ II *с.* 1. *физиол.* Тышкы тәэсиргә җавап бирергә сәләтле.

2. *физ.* Атылып чыккан газ көче белән барлыкка килгән. *Реактив хәрәкәт.* □ *Уйлап табучы һәм галим К. Э. Циолковский, планеталар арасында элемтә тоту мөмкинлеген нигезләп, реактив хәрәкәт теориясен эшләде.* СССР тарихы. || Шундый көч ярдәмендә хәрәкәт итә торган. *Реактив самолет. Реактив двигатель. Реактив снаряд.* □ *Реактив истребительләрдә тавыштан да тизрәк очып йөргәнгәме, --- саулыгын какшатып, отставкага чыкты* [*Зиннәт*]. Э. Касыймов.

РЕАКТИВЛЫК *и.* 1. *хим.* Реакция ясауга сәләтле булу, реактив (I) булу. *Матдәнең реактивлыгы.*

2. *физиол.* Тышкы тәэсирләргә җавап бирергә сәләтле булу.

РЕА'КТОР *и.* 1. *махс.* Кыска ялганыш вакытында алмаш ток чылбырындагы токны чикләү һәм җитәрлек көчәнеш булдыру өчен электр аппараты.

2. *хим.* Билгеле басым һәм температурада химик реакция ясау өчен аппарат. *Шул арада, Зөлфәнең бәхетенә, реактордан анализга аксыл-соргылт эремә алып керделәр.* Э. Касыймов.

3. *физ.* Атом төшләре бүленешенең идарә ителә торган чылбыр реакциясе башкарыла торган җайланма. *СССР Фәннәр академиясе каршындагы береңче атом электростанциясендә уран-графит реакторы кулланылган.* Физика.

РЕАКЦИОН *с.* Реакция (II) интересларын күзәтә торган, шул интересларга хезмәт итә торган; яңага, алдынгыга каршы булган, искене, бетүгә йөз тоткан-ны яклый торган. *Реакцион политика.* □ *Син, энем, реакцион министр Шингарев приказындагы җырны җырлап, крестьяннарны авызлыкларга чакырасың.* Т. Гыйззәт. [*„Яңа Кисекбаш"та*] *Г. Тукай надан, тискәре, бозык, реакцион хаҗилар, муллалар, сәүдәгәрләр, ялкау, әрәмтамак шәкертләрдән көлә.* М. Җәлил.

РЕАКЦИОНЕР *и.* Политик реакцияне яклаучы кеше; һәртөрле социаль һәм культура прогрессына каршы, дошман кеше; кадимче. [*Печән базары эһелләре арасында*] *мәгълүм Галимҗан Баруди хәзрәт һәм реакционерның да реакционеры Сәйдәшев бай күренә.* А. Расих.

РЕАКЦИОНЛЫК *и.* Реакцион булу. *Фикернең реакционлыгы. Политиканың реакционлыгы.*

РЕА'КЦИЯ I *и.* 1. Нинди дә булса тәэсиргә, йогынтыга җавап буларак барлыкка килгән эш-хәрәкәт, каршы җавап. *Мөгамәләдә тупаслыкның үзенә карата тиешле реакция тудыруы.* || *физиол., биол.* Организмның тышкы тәэсиргә, ярсыткычка каршы җавабы. *Организмның суыкка реакциясе.*

2. *хим.* Ике яки берничә матдәнең үзара тәэсир итешүе. [*Реакторларда*] *хлорлы барий белән каустик сода эремәләре кушылып, үзара реакциягә керә.* Э. Касыймов.

РЕА'КЦИЯ II *и.* Гомере бетеп бара торган яки революция тарафыннан җиңелгән эксплуататор сыйныфларның революцион хәрәкәтне һәм һәртөрле иҗтимагый прогрессны рәхимсез бастыру юлы белән үзләренең хокукларын һәм политик хакимлеген кире кайтару яки саклап калу өчен алып барган көрәш политикасы. — *Инде менә авылда крестьянны тереләй суеп, байлык җыючы кулак, реакция каһарманы Нигъмәт казыең да килеп төште.* Г. Ибраһимов. *1905 елгы революция бастырылганнан соң илдә көчле реакция башланды.* М. Җәлил. || Алдынгының, яңаның үсешенә һәртөрле каршылык күрсәтү. [*Зыя:*] *Искелләр арасында көннән-көн яшьләргә каршы реакция --- куәтләнә бара.* Ф. Әмирхан.

РЕАКЦИЯЧЕЛ *с. кит. к.* реакцион. *Буржуа катлаулары вәкилләреннән торган беренче Дума да патшаның реакциячел хөкүмәте каршында сул табылып кудырылды.* Г. Нигъмәти.

РЕАЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Милекне яки кыйммәтле кәгазьләрне (мәсәлән, заемны) акчага әйләндерү, сату. *Социалистик предприятиеләр үзләренең продукцияләрен товар әйләнеше процессында план белән билгеләнгән бәяләр буенча реализацияләләр.* Политэкономия.

РЕАЛИЗМ *и.* 1. Тормышчанлык, реальлек; тормышка аек карау; тормыш шартларын исәпкә алып эш итү.

2. Тормышны, чынбарлыкны типик образлар аша тулы һәм дөрес чагылдыра торган художество методы; сәнгатьтә, әдәбиятта шул методка нигезләнгән юнәлеш, агым. *Реализм — чынлыкны (әйләнә-тормышны) бар көенчә дөрес итеп чагылдыруны шарт итә.* М. Җәлил. *Узган гасырның беренче яртысында, имештер, реализм белән беррәттән романтизм да, сентиментализм да --- бергә үрелеп үскәннәр.* М. Хәсәнов.

3. *филос.* XIX йөз философиясендә идеализмга капма-каршы юнәлешләрне билгеләү өчен кулланылган термин. || Хәзерге буржуаз философиядәге кайбер юнәлешләр (мәсәлән, неореализм, критик реализм һ. б.) вәкилләре тарафыннан, гадәттә, үзләренең идеалистик йөзләрен яшерү өчен кулланыла торган термин.

4. *филос.* Урта гасыр философиясендә: гомуми төшенчәләр әйберләргә кадәр булалар һәм алардан бәйсез рәвештә реаль яшиләр дип санаган дини-идеалистик юнәлеш.

РЕАЛИСТ *и.* 1. Реаль тормыш шартларын (практик мөмкинлекләрне) исәпкә алып эш итүче кеше.

2. Сәнгатьтә һәм әдәбиятта реализм тарафдары, реализм методы белән иҗат итүче (язучы, художник һ. б.). *Чехов әдәби иҗат мәсьәләсенә карашта, үзенең хикәя язучылыкта булган мөгаллиме Мопассан шикелле үк, реалист һәм натуралист.* Г. Нигъмәти.

3. *филос.* Реализм (4 мәгъ.) тарафдары.

4. Революциягә кадәрге Россиядә реальный училище укучысы. — *Мулланур Вахитов, реалист, менә үзегез күргәнчә, бик чибәр һәм хәйләкәр егет.* А. Расих.

РЕАЛИ'СТИК *с.* 1. Реаль чынбарлыкны исәпкә алып эш итә торган. *„Кыю кызлар"ны сәхнәгә куючы режиссер Вәлиев-Сульва --- реалистик, ышандырырлык күренешләр тудыра алган.* М. Җәлил.

2. Реализм (2 мәгъ.) принципларына нигезләнгән. *Музыкада реалистик юнәлеш. Реалистик роман.* □ *Тәрҗемә әсәрләр татар сәхнәсенә яңа стиль, реалистик сәхнә методы алып киләләр.* Сов. әд.

РЕАЛИСТЛЫК *и.* Реалист булу сыйфаты. *„Безнең көннәр" Г. Ибраһимовның романтик-идеалистлыктан реалистлыкка үсүендә бер этап.* Г. Нигъмәти.

РЕАЛЬ *с.* 1. Чын, чынбарлыкта (тормышта) булган, уйлап чыгарылмаган. *Реаль шартларга бәя биреп бетермәү һәм үз-үзеңә артык ышаныч — менә нәрсә белән авырый булырга кирәк* [*Каюм*]. Ш. Камал. *Г. Камал биргән типлар—хәзерге көн өчен дә үзләренең актуальлеген югалтмаган, реаль, җанлы кешеләр.* М. Гали. || *рәв. мәгъ.* Тормыштагыча, чынбарлыкта булганча. *Әдәби әсәрләрдә тормышны реаль чагылдыру. Тормышка реаль карау.* || *и. мәгъ.* Чын, хакыйкать. *Бүген без хыялланган автоматика реальгә әвереләчәк.* Соц. Тат.

2. Тормышның асылын, төп шартларын аңлап эш итә торган; тормышчан. *Реаль политика.*

3. Гамәлгә (эшкә, тормышка) ашарлык, тормышка ашырырга, үткәрергә мөмкин булган, тормышчан. *Реаль план.* □ [*Квартира бирү мәсьәләсе*] *бары вәгъдә генә. Ләкин аныcы да әле күренеп торган реаль нигездә түгел.* Г. Әпсәләмов. || Төп, нигез, мөһим. *Татар опера театрының төзелүе реаль бурыч булып алга басу --- татар композиторларының игътибарын опера иҗат итүгә борды.* М. Җәлил.

Реаль фәннәр *иск.* — сынау, тәжрибә, экспериментларга нигезләнгән фәннәр; табигать фәннәре, төгәл фәннәр. **Реаль эш хакы** — эш хакының сатып алу сәләте.

РЕАЛЬЛЕК *и.* Реаль, тормышчан булу сыйфаты. *Тәкъдимнең реальлеге.* □ *Үзенең эчтәлеге, образларның тулылыгы, реальлеге белән* [*„Уйнаш“ драмасы*] *капиталистик тормышның иң --- караңгы якларын ачып бирә.* М. Гали. *Хәзерге көннең ачышлары икмәкне, шикәрне, сөт продуктларын һ. б. синтезлау юлы белән ала башлауның реальлеген күрсәтәләр.* Соц. Тат.

РЕАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Эшкә, тормышка ашыру, гамәлгә ашыру, нәрсәне дә булса башкарып чыгу.

РЕАЛЬЛӘШҮ *ф.* Эшкә (тормышка) ашу, гамәлгә ашу.

РЕА'ЛЬНЫЙ: реальный училище *и. иск.* — революциягә кадәрге Россиядә күбрәк төгәл һәм табигать фәннәре укытыла торган урта уку йорты. [*Хәйдәр Акчулпанов*] *реальный училищеның алтынчы сыйныфында чакта ук үзе кебек реалистлардан бер яшерен сәяси түгәрәк төзеде.* Г. Ибраһимов.

РЕ'БУС *и.* 1. Рәсемнәр, хәрефләр, билгеләр комбинациясеннән торган табышмак сүз, фраза, әйтем, мәкаль, шигырь өзеге һ. б. ш.

2. *күч.* Чуалчык мәсьәлә, аңлаешсыз нәрсә.

РЕВАКЦИНА'ЦИЯ *и. мед.* Икенче кат ясалган вакцинация.

РЕВАНШ *и.* Сугышта яки уенда җиңелгән якның үч кайтару теләге белән уенны яки сугышны яңадан булдыруга омтылышы; җиңелгән якның җиңүчедән өстен чыгу өчен алып барган көрәше. *Хәтта Совет гаскәрләре Берлин төбенә килеп җиткән хәлдә дә әле, Гитлер яңа реванш алырга җыена.* Н. Дәүли.

РЕВАНШИ'ЗМ *и.* Берәр дәүләтнең сугышта җиңелгәннән соң реванш алырга омтылуы; реванш алу йөзеннән яңа сугыш хәзерләүгә юнәлдерелгән политика; буржуазиянең империалистик, басып алу сугышларын хәзерләү политикасы.

РЕВАНШИСТ *и.* Реванш алучы яки реванш алырга омтылучы; реваншизмны яклаучы, реваншизм тарафдары. *Немец реваншистлары.*

РЕВАНШИ'СТИК *с.* Реваншизм яклы булган; реваншизмны пропагандалаган. *Реваншистик политика. Реваншистик армия.*

РЕВАНШ'ИСТЛЫК *и.* Реваншист булу. *Реваншистлык омтылышлары.*

РЕВАНШЧЫ *и.* 1. *к.* реваншист. *Фашист реваншчылары.*

2. *с. мәгъ.* Реванш алуны яклаган; реваншизм яклы. *Реваншчы көчләр.*

РЕВА'НШЧЫЛЫК *и. к.* реваншистлык.

РЕВЕНЬ *и. бот.* Яшь сабаклары ашамлык (кесәл, компот һ. б.) хәзерләү өчен файдаланыла торган, яфраклары әрекмән яфрагына охшаган, калын тамырлы күпьеллык үлән үсемлек.

РЕВЕРА'НС *и.* Дворяннар һәм буржуазия тормышында: хатын-кызларның ихтирам йөзеннән җиңелчә тез чүгеп сәламләве. [*Кечкенә кыз*] *тиз генә бөтен нечкәлекләре белән реверанс ясап алды да кәрзинен Илсөяргә сузды.* Г. Гобәй.

РЕВЕРБЕРА'ЦИЯ *и. физ.* Тавыш туктагач та, тавыш дулкыннарының ябык бина стеналарына бәрелеп кире кайтарылуы аркасында тавыш яңгыравы.

РЕ'ВЕРС *и.* 1. Медальнең яки металл акчаның кире (арткы) ягы, иләк як.

2. *экон.* Нәрсәне дә булса гарантияләүне үз өстенә алу.

3. *махс.* Машинаның хәрәкәт итү юнәлешен кире якка үзгәртергә мөмкинлек бирә торган механизм.

РЕ'ВЕРСЛАУ *ф.* Хәрәкәт юнәлешен киregә таба үзгәртү.

РЕВЕ'РСЕР, РЕВЕ'РСОР *и. махс.* Двигатель валларының әйләнү юнәлешен үзгәртү өчен хезмәт итә торган җайланма.

РЕВЕРСИВ *с. махс.* Әйләнү яки хәрәкәт итү юнәлешен үзгәртеп була торган. *Реверсив двигатель. Реверсив мотор.*

РЕВЕ'РСИЯ *и.* 1. *биол.* Борынгы бабаларында булып та якын бабаларында очрамаган билгеләрнең организмда яңадан килеп чыгуы; атавизм.

2. *юр.* Милекне әлекке иясенә кайтару.

РЕВЕ'РСИЯЛӘҮ *ф.* Реверсия (2 мәгъ.) ясау.

РЕВИЗ *и. сөйл. к.* ревизия (3 мәгъ.). *Урта хәлләр үзара җир бүлешеп, „иске ревиз“, „яңа ревиз“ дип талашып гомер үткәрәләр.* Г. Ибраһимов.

Ревиз исемлеге — ясак түләүчеләрнең ревизиядән (3 мәгъ.) соң төзелгән исемлеге.

РЕВИЗИОНИЗМ *и.* 1. Революцион марксизмның политик, философик һәм экономик нигезләрен яңадан карап яки бозып, инкяр итеп, аларны социалистик революция һәм пролетариат диктатурасына каршы юнәлдерелгән, фәнни булмаган теорияләр белән алмаштырырга тырышкан реакцион идея-политик агым.

2. Берәр теорияне, тәгълиматны ревизияләүгә юнәлдерелгән агым.

РЕВИЗИОНИСТ *и.* Ревизионизмны яклаучы; ревизионизм тарафдары. *В. И. Ленин марксизм философиясенә буржуаз идеологлар һәм ревизионистлар ясаган барлык атакаларны кире какты.* КПСС тарихы.

РЕВИЗИОНИСТЛЫК *и.* Ревизионист булу.

РЕВИЗИЯ *и.* 1. Эш итүнең дөреслеген, законлылыгын билгеләү **мак**саты белән нинди дә булса учреждениенең, урындагы кешенең эшен тикшерү. *Магазинга ревизия ясау.* □ *Тик ревизия вакытында* [*Сәйфинең*] *бит бер генә кило да тулмаучылыгы чыкмый торган иде.* Г. Бәширов. || *сөйл. шаяр.* Үзеңә кирәк нәрсәне тикшереп карап чыгу.

2. Берәр тәгълиматның яки теориянең нигезен боза торган үзгәрешләр кертү максаты белән аның төп положениеләрен яңадан карау. *Марксизмга ревизия.*

3. *тар.* XVIII йөздә һәм XIX йөзнең беренче яртысында Россиядә җан башына салым салу өчен авыл һәм шәһәр халкы санын исәпкә алу.

РЕВИ'ЗИЯЛӘҮ *ф.* Ревизия (1 мәгъ.) ясау, тикшерү үткәрү.— *Сез* [*Иван Ильичның*] *эшен ревизияләргә җыенмыйсыздыр бит?* А. Расих.

РЕВИЗОР *и.* 1. Ревизия (1 мәгъ.) ясаучы дәүләт хезмәткәре. *Председатель булып эшли башлагач, мин районнан ревизор чакырттым.* Г. Ахунов.

2. Тимер юл контролеры.

РЕВИЗОРЛЫК *и.* Ревизор булу. *Ревизорлык бурычлары. Ревизорлык эше.*

Ревизорлык итү — ревизор хезмәтен башкару, ревизор булып эшләү.

РЕВКОМ *и.* Хәрби революцион комитет: кораллы восстаниене хәзерләү һәм үткәрү өчен 1917 елда төз-

зелгән сугышчан орган. *Без ревкомда соңгы сугышка хәзерләнгәндә, ул ревком бүлмәсенә пулемет сөйрәп керде.* Г. Әпсәләмов. || Революцион яки хәрби революцион комитет (гражданнар сугышы һәм чит илләр хәрби интервенциясе вакытында Совет властеның урындагы гадәттән тыш органы). || *с. мәгъ.* Ревкомга бәйләнешле. *Ревком члены.*

РЕВМАТИЗМ *и.* Йөрәк-кан тамырлары системасының, буыннар һәм мускулларның көчле сызлап авыртуы белән бәйле авыру; коры сызлау. [*Идрис:*] *Миндә ревматизм, җәяү бер адым да атлый алмыйм.* Т. Гыйззәт. [*Мәдинәнең*] *анасы ревматизм белән авырып китте.* Ш. Хөсәенов.

РЕВМАТИ'ЗМЛЫ *с.* Ревматизм белән авырый торган. *Полкның командиры — отставной подполковник, --- ревматизмлы аякларына бурки белән резин галошлар кигән, килбәтле генә кыяфәттә, --- „тантананың" үзәгендә тора.* Ш. Камал.

РЕВМА'ТИК *и.* Ревматизм авырулы кеше.

РЕВОЛЬВЕР *и.* Әйләнмә барабан сыман магазины булган, ата торган күп зарядлы кечкенә корал; алтатар. [*Фрунзеның*] *артыннан кайсы шинель, кайберләре кызыл күн тужурка кигән, төрле револьверлар, кылычлар таккан тагын берничә кеше кереп китте.* Г. Бәширов. *Кулына револьвер тоткан Закир дошманын бирелергә мәҗбүр итә.* М. Җәлил.

Револьвер станок — берничә инструмент куелышлы борылма җайланмасы булган кыру станогы.

РЕВОЛЬВЕРЧЫ *и.* Револьвер станокта эшләүче токарь.

РЕВОЛЮЦИОН *с.* 1. Революциягә (1 мәгъ.) бәйләнешле. *Революцион бәйрәм. Революцион гимн.* □ *Мин бу хатны --- бер революцион җыр сүзләре белән тәмамлыйм.* К. Нәҗми.

2. Революция (1 мәгъ.) идеяләрен алга сөргән; революция рухы белән сугарылган; революция талэпләренә, ихтыяҗларына туры килә торган, революцияне яклаган. *Революцион теория. Революцион сыйныф. Революцион көрәш.* □ *Казанда революцион хәрәкәт көчәйгәннән-көчәя, ләкин шулай да җитәрлек оешкан төс алмаган.* А. Расих. || Революция тарафыннан, революция нәтиҗәсендә булдырылган, урнаштырылган. *Революцион власть.* □ *Казанда Вакытлы революцион комитет төзелде.* И. Гази. || *рәв. мәгъ. сөйл.* Революция күзлегеннән карап; революцияне яклап, революция талэпләренә, ихтыяҗларына туры китереп. [*Әхмәт:*] *Минемчә, бу мәсьәләгә ул вак буржуача карый.* [*Каюм:*] *Һәрхәлдә революцион карый дип әйтеп булмый.* Ш. Камал.

3. *күч.* Нинди дә булса бер өлкәгә кискен үзгәрешләр кертә торган; нәрсәне дә булса тамырыннан үзгәртеп кора торган. *Революцион алга китеш. Культура өлкәсендә революцион үзгәреш.*

РЕВОЛЮЦИОНЕР *и.* 1. Революцион хәрәкәткә катнашучы көрәшче; революция эшлеклесе.— *Уйлап кара, балакай, син, бәлкем, үзегезгә килеп йөргән революционерларның кайда торганлыкларын әйтерсең.* Г. Гобәй. *Профессиональ революционер, куркыныч реаль булганда, үзе дә бер эзгә ике тапкыр басмый.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Фәннең, техниканың, сәнгатьнең һ. б. ш. берәр өлкәсендә тамырыннан үзгәреш кертүче (кеше). *Фән революционеры.*

РЕВОЛЮЦИОНЕРЛЫК *и.* Революционер булу. [*Мирвәли:*] *Син хәзер революционерлык юлына басып барасың икән.* Т. Гыйззәт.

РЕВОЛЮЦИОНЛАШТЫРУ *ф.* Революция яклы итү, революция рухы белән сугару. [*Рус эшчеләре, галимнәре һ. б.*] *Урта Азиядәге халыкларны культуралаштыруда һәм революционлаштыруда бик зур роль уйнаганнар.* СССР тарихы.

РЕВОЛЮЦИОНЛАШУ *ф.* Революция яклы булып әверелү. [*1907—1917 еллар арасындагы*] *дәвер* [*М. Гафуриның*] *көннән-көн революционлаша баруы --- белән характерлы.* М. Җәлил. *Россия империализмның барлык каршылыкларының төен пункты булып чыкты, бу хәл пролетариатның революционлашу --- процессын бик нык көчәйтте.* Политэкономия.

РЕВОЛЮЦИОНЛЫК *и.* Революцион булу сыйфаты.

РЕВОЛЮЦИЯ *и.* 1. Гомерне беткән җәмгыять строен көч куллану юлы белән бәреп төшереп, аның урынына яңа, прогрессив строй урнаштыру, җәмгыять тормышын тамырыннан үзгәртеп кору эше. *Бөек Октябрь социалистик революциясе.* □ *Алга атлаган һәрбер адымыбыз безне дөнья революциясенә якынайтсын.* М. Максуд. *Һәм менә, нинаять, революциянең язмышын хәл иткән тугыз йөз дә унтугызынчы ел килеп җитте.* А. Расих.

2. *күч.* Фәннең, техниканың, сәнгатьнең һ. б. ш. берәр өлкәсендә төпле үзгәреш, кискен алмашыну. [*Су белән бораулау*] *барып чыкса, --- ике тапкыр, өч тапкыр тизрәк бораулый башлыйбыз. Бу бит бораулау эшендә революция!* И. Гази. — *Культура революциясе бездә --- киң колач җәйде.* Г. Бәширов.

РЕВОЛЮ'ЦИЯЧЕ *с. к.* революциячел. *Революцияче партияләр идән астына киттеләр.* Г. Нигъмәти.

РЕВОЛЮ'ЦИЯЧЕЛ *с.* Революция яклы булган. [*Казакларның*] *берәве фронттагы иң революциячел казачий полкларның берсендә, икенчесе Петроград урамнарында революция рухы белән тәрбияләнеп өлгергәнлектән, бер-берсе белән дуслашып алганнар.* Ш. Усманов.

РЕВТРИБУНАЛ *и.* Контрреволюцион элементларга һәм саботажникларга каршы көрәш алып бару өчен 1917 елда Совет хөкүмәте тарафыннан төзелгән һәм 1922 елгы суд реформасына кадәр яшәгән суд учреждениеләренең исеме; *русчасы:* революционный трибунал.

РЕВЮ *и.* Гадәттә, актуаль темага караган аерым күренешләрдән, номерлардан төзелгән театр яки эстрада постановкасы.

РЕГА'ЛИЯ *и. иск.* 1. Падишаһлык билгесе яки символы булган әйбер (таж, скипетр һ. б. ш.). *Патша регалияләре.*

2. *сөйл., иск.* Орден, медаль һ. б. ш. *Сафа унтер* [*мәчеткә намазга кергәндә*] *--- регалияләрен салып куя, чөнки арада бер тәре, патша башы сурәте төшкән медале бар.* И. Рәмиев.

РЕГА'ТА *и. спорт.* Ишкәкле, җилкәнле яки моторлы көймәләрдә зур ярыш.

РЕ'ГБИ *и. спорт.* Футбол уенының бер төре. *Командалар регби уенындагы кебек унарлап өлешләр.* А. Гыйләҗев.

РЕГБИЧЫ *и. спорт.* Регби уйнаучы.

РЕГЕНЕРАТ *и. тех.* Файдаланылганнан соң яңадан эшкә яраклы хәлгә китерелгән материал.

РЕГЕНЕРАТИВ *с. тех.* Регенерациядән гыйбарәт. *Регенератив процесс.* || Регенерация өчен билгеләнгән, регенерация өчен хезмәт итә торган.

РЕГЕНЕРА'ТОР *и.* Мичкә керә торган һаваны җылыту өчен регенерация миченең камера сыман итеп эшләнгән өлеше. *Регенераторның насадкасын мичтән чыга торган газлар җылыта. Ул җитәрлек дәрәҗәдә җылынгач, регенератор аша мичкә һава кертә башлыйлар.* Химия.

РЕГЕНЕРА'ЦИЯ *и.* 1. *тех.* Файдаланылган материалларны билгеле операцияләр ярдәмендә яңадан эшкә яраклы итү, элекке хәленә кайтару. *Мумия сөяк регенерациясенә бик актив тәэсир итүе белән аеруча дан казанды.* Соц. Тат.

2. *биол.* Тән, әгъза, тукыма, күзәнәкләрнең юкка чыккан яки зарарланган өлешләрен организмның яңадан торгызуы. [*Гидраны*] *берничә кисәккә тураларга мөмкин. Уңайлы шартлар булганда, һәр кисәгеннән гидра үсеп китә. Мондый күренеш регенерация дип атала.* Зоология.

РЕГЕНЕРА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Регенерация (1 мәгъ.) ясау. *Нурмөхәммәт яңа төзелеп яткан автоматик регенерацияләү корпусына таба атлады.* Каз. утл.

РЕ'ГЕНТ *и.* Монарх урынында вакытлыча хөкүмәт башында торучы; вакытлыча падишаһлык итүче; идарәче. *Регент итеп патшаның энесе бөек князь Михаилны куя күздә тотыла иде.* КПСС тарихы.

РЕ'ГЕНТЛЫК *и.* Монархияле илләрдә: монархның авыруы, яшь булуы, кая да булса озак вакыт китеп торуы һ. б. ш. сәбәпләр аркасында бер яки берничә кешенең вакытлыча дәүләт белән идарә итүе.

РЕГИОНАЛЬ *с.* Нинди дә булса аерым бер өлкәгә, илгә яки бер урындагы берничә өлкәгә, илгә бәйләнешле; җирле, урындагы. *Региональ конференция.*

Региональ пакт — билгеле бер географик өлкәдәге дәүләтләр арасында төзелгән халыкара килешү.

РЕГИСТР *и.* 1. Белешмә исемлек, күрсәткеч; теркәү кенәгәсе.

2. *муз.* Җырчы тавышының яки музыка коралы тавышы диапазонының (югарылык-түбәнлек буенча) урыны. *Тромбон һәм контрабасларның хакимлек итәргә тырышкан шомлы авазларын ярып, тагын скрипкалар калыкты. Югары регистрга ыргылучы флейталар тагын үз темаларын алга сөрделәр.* Ш. Хөсәенов.

3. Клавишларына басып уйный торган тынлы һәм телле музыка коралларында (орган, фисгармония, аккордеон һ. б.) бердәй тембрдагы трубалар яки телләр группасы. *Беренче Бөтенроссия күргәзмәсенә М. Д. Вараксин ул заман өчен бөтенләй яңа, күп регистрлы гармонь ясап китерә.* Каз. утл. || Язу машинасында хәрефләр һәм клавишлар рәте.

4. Машина һәм приборларда регулятор. *Сумматорлардан, шуыштыручылардан һәм регистрлардан тапкырлаучы җайланма җыела.* Уйлаучы машиналар.

5. Төзелә торган һәм эксплуатациядә булган елга һәм диңгез судноларының сыйфатын, техник куркынычсызлыгын тикшерүче дәүләт органы. *Чиновник соңгы портта биргән карантин таныклыгын, регистр рөхсәтен карады.* Каз. утл.

РЕГИСТРА'ТОР *и.* 1. Регистрация алып баручы, регистрацияләүче.

2. *махс.* Кәгазьләрне теркәп саклау өчен махсус картон папка.

РЕГИСТРА'ТОРЛЫК *и.* Регистратор (1 мәгъ.) вазифасы; регистратор булу. *Регистраторлык эше.*

РЕГИСТРАТУ'РА *и.* Учреждениедә регистрация алып бару бүлеге.

РЕГИСТРА'ЦИЯ *и.* 1. (Кенәгәгә) язып теркәп кую; исемлеккә кертү; реестрга кертү. *Регистрациядән соң район делегатлары: „Татар театрына барасыбыз килә" — дип, Гөлшаһидәне дә үзләре белән чакырдылар.* Г. Әпсәләмов. || Законлаштыру, рәсмиләштерү максаты белән нәрсәне дә булса билгеле тәртиптә язып билгеләп кую (бару). *Дивизия комитетыннан алынган удостоверениесе буенча регистрацияга кертелеп, нинди эш алып барырга --- тиешлек турында секретарь тарафыннан* [*Габдуллага*] *бераз нәрсәләр сөйләнде.* Ш. Камал.

2. Никахны законлаштыру. [*Таипов:*] *Иптәшләр, хәзер җирле граждан эшләре башында торучы Ногманов иптәшкә яшьләрнең регистрацияләре турында хәбәр итү өчен сүз бирелә.* Ф. Бурнаш. [*Ул*] *минем законлы хатыным, — дидем мин. — дгәр без регистрациядә булмаганбыз икән, эш ул мәсьәләне хәл итми.* А. Шамов. || Нинди дә булса күренешне, фактны язып теркәп кую (бару). *Ракетага Айның магнит кырын, Айның радиоактивлыгын --- регистрацияләү --- аппаратлары урнаштырылды.* Космик ракеталар.

РЕГИСТРА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Регистрация ясау (үткәрү), теркәү.

РЕГЛА'МЕНТ *и.* Утырышлар, җыелышлар алып бару тәртибе. *Регламент билгеләү.* □ *Д Шакир, кая куйсаң да, Үз туксанын туксанлый, Регламентыңны да белми, Сөйли бирә, туктамый.* Ш. Галиев.

РЕГЛА'МЕНТЛАШТЫРУ *ф.* Нәрсәне дә булса төгәл, дөрес билгеләү, тиешле тәртип кертү. || Тәртипкә салу (китерү); билгеле кагыйдәләргә буйсындыру. *Цехлар --- җитештерү процессын регламентлаштырганнар: алар эш көненең озынлыгын, һәр мастерның ярдәмчеләренең һәм өйрәнчекләренең санын билгеләгәннәр.* Политэкономия.

РЕГЛАН *с.* Инбашы белән җиңе бертоташ итеп киселгән. *Реглан күлмәк.* || *и. мәгъ.* Шулай тегелгән өс киеме.

РЕГРЕСС *и.* Үсештә артка китеш, артка чигенеш; бетүгә йөз тоту; *киресе:* прогресс.

РЕГРЕССИВ *с.* Үсештә артка илтә торган, регрессқа алып бара торган; бетүгә йөз тоткан. *Регрессив күренеш.* || Реакцион, антидемократик. *Регрессив чаралар.*

Регрессив ассимиляция *и. лингв.* — алдагы авазның үзеннән соң килгән авазга охшашлануы; кире ассимиляция (мәсәлән, тозсыз — тоссыз, кызса — кысса).

РЕГУЛИРО'ВЩИК *и.* 1. Борылмаларда, урам һәм юл чатларында транспорт хәрәкәтен тәртипкә салып торучы хезмәткәр.

2. Механизмнарның эшен, хәрәкәтен җайга салучы (көйләүче) белгеч.

РЕГУЛЯР *с.* Даими һәм эзлекле рәвештә, әледән-әле булып тора торган; кабатлана торган. || *рәв. мәгъ.* Даими рәвештә, эзлекле рәвештә, тәртипле рәвештә, әледән-әле, үз вакытында. *Ай өстенең фототелевизион сурәтләре һәм төрле телеметрик информацияләр регуляр рәвештә җиргә тапшырылды.* Соц. Тат.

Регуляр армия, регуляр гаскәр — ныклы куелган хәрби оешмасы булган һәм планлы рәвештә хәрби хәзерлек алып тора торган даими гаскәрләр. *— Ну кыйраттык та без* [*немецларны*] *ичмаса! Тегеннән безнең регуляр частьлар куа килә, без арттан һәм кабыргадан пешерәбез.* Ш. Маннур. *— Бу сиңа 18 нче ел түгел, моны сиңа 1920 елгы регуляр армия, Кызыл Армия диләр!* Г. Бәширов.

РЕГУЛЯТИВ *с.* Планлылык, тәртип кертә торган; юнәлеш бирә торган. *Регулятив идея.*

РЕГУЛЯ'ТОР *и.* Механизмның эшен, хәрәкәтен автоматик рәвештә җайлый (көйли) торган прибор. *Тизлек регуляторы. Үзәктән кугыч регулятор.* □ *Кранның кабинасы паровоздагы машинист будкасына бик охшаган, --- манометр, регулятор, тормоз рычаглары — һәммәсе дә бирегә тупланган.* С. Сабиров.

РЕД- Кайбер кушма сүзләрдә „редакцион" дигән мәгънәне белдерә торган беренче кисәк, мәсәлән: **редколлегия, редсовет.**

РЕДА'КТОР *и.* 1. Нинди дә булса текстны редакцияләүче. *Әдәби редактор. Техник редактор.* □ [*Шиһапов*] *менә күп еллар инде нәшрияттә редактор булып хезмәт итә.* И. Гази.

2. (Китап, газета, журналларны һ. б.) бастырып чыгару эшенә җитәкчелек итүче, аның эчтәлеген билгеләүче һәм раслаучы. *Җаваплы редактор.* □ *Уртадагы зур өстәл артында комиссариат әгъзасы Садри белән газета редакторы Зиннәт ниндидер бер мәсьәлә турында кызып бәхәсләшеп утыралар.* Ш. Усманов.

РЕДА'КТОРЛЫК *и.* Редактор вазифасы, хезмәте. [*Г. Камалның*] *газетачылык эшендәге хезмәтләре, корректорлыктан һәм гади тәрҗемәчелектән башлап, редакторлыкка кадәр барып җитә.* М. Гали. *Гомәр Гали редакторлыгында минем --- институт тәэсирләрен нигезгә салып язган хикәяләр җыентыгым басылып чыккан иде.* Ф. Хөсни.

РЕДАКЦИОН *с.* Редакцияләүгә, редакциягә мөнәсәбәтле. *Редакцион төзәтмәләр.*

РЕДА'КЦИЯ *и.* 1. Текстны эшкәртү, төзәтү эше; редакцияләү. *Дәрнең соңгы редакциясенә керешү.*

2. (Китап, газета, журналларны һ. б.) редакцияләү эшенә җитәкчелек итү. *Профессор редакциясендә чыккан китап.*

3. Берәр фикернең, положениенең тәгъбир ителеше, формулировкасы. *Бәлки, Дина кул куярлык итеп, актны икенче редакциядәрәк язарга кирәктер.* С. Рафиков.

4. Әдәби, музыкаль һ. б. ш. әсәрләрнең беренче башлап язылган яисә аның соңыннан үзгәртүләр, яңадан эшкәртүләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән варианты. *Пьесаның беренче редакциясе 1900 елда „Өч бәдбәхет“ исемендә „Казанай“ имзасы белән --- басылып чыга.* М. Гали.

5. Нәшриятта: кулъязмаларны бастырып чыгаруга әзерләү эшен башкара торган бүлек. *Газета редакциясе. Журнал редакциясе.* □ *Яңа ел номеры материаллары типографиягә төшерелгәч, редакциядә көндезге эш бетте.* Г. Минский. || Кулъязма текстны эшкәртү һәм аны бастырып чыгаруга әзерләү өстендә эшләүчеләр төркеме; редакторлар коллективы. *Авыз ачып, бөтен редакция Иректән аңа караган.* З. Мансур. *Редакция халкы Мусаны читсенми кабул итте.* Ш. Маннур.

6. Редакция (5 мәгъ.) урнашкан бина (бүлмә). *Яхшы хәтерлим, элек „Безнең юл“ редакциясе Кремльдә, хәзерге Мәгариф министрлыгы урнашкан бинаның --- кечкенә генә бер бүлмәсендә иде.* Ф. Хөсни.

РЕДА'КЦИЯЛӘҮ *ф.* 1. Нинди дә булса текстны укып төзәтү (дөресләү); аны басу өчен әзерләү. *Кулъязманы редакцияләү.* □ [*Шәйхетдинов*] *үзе кебек үк матур әдәбият китаплары редакцияләүче Шиһапов белән икәү генә бер бүлмәдә утырып эшли иде.* И. Гази. [*Идрис*] *иң әүвәл --- чираттагы санга ике мәкаләне редакцияләде, берничә хатка җавап язды.* А. Гыйләҗев.

2. Китап, газета, журналларны һ. б. басарга әзерләү, төзәтү һәм бастырып чыгару эшенә җитәкчелек итү. *Муса оешманың җаны булып әверелә, ул бюроны да җитәкли, газетаны да редакцияли.* Г. Кашшаф.

РЕДИС *и.* Әвернәчәчәклеләр семьялыгына керә торган тиз өлгерешле берьеллык яшелчә үсемлек. *Кәбестә һәм помидор рәтләре арасына кыяк суган, редис яки салат чәчәләр.* Җиләк-җимеш... || Шул үсемлекнең зур булмаган бүлбесе (формасы белән чөгендергә, тәме белән әче тормага тартым; кабыгы кызыл, эче ак яки алсу төстә). *Редистан салат ясау.* □ *Апшеронда яңа кишер һәм редис өлгерде.* Соц. Тат.

РЕДИ'СКА *и. к.* редис.

РЕДУ'КТОР *и.* 1. Бер валның әйләнешен икенче валга күчергәндә әйләнү тизлеген үзгәртә торган тешле механизм.

2. Трубопровод буенча ага торган сыекча яки газның басымын төшерү яисә басымның даимилеген саклау өчен хезмәт итә торган прибор. *Кислород редукторы.* □ *Кысылган газ редуктор аша ягулык багына керә.* Космик ракеталар.

РЕДУКЦИОН *с.* Редукциягә бәйләнешле.

РЕДУ'КЦИЯ *и.* 1. *махс.* Катлаулы күренешнең гади күренешкә күчүе яки күчерелүе.

2. *биол.* Функцияләрен югалту сәбәпле, организмдагы берәр орган төзелешенең гадиләшүе; органның күләме кечерәюе яки бөтенләй бетүе.

3. *лингв.* Авазлар кыскаруы. *Басымсыз иҗекләрдә сузыклар редукциясе.*

РЕДУ'КЦИЯЛӘҮ *ф.* Редукция (1 мәгъ.) булдыру, барлыкка китерү.

РЕДУПЛИКА'ЦИЯ *и. лингв.* Тамыр сүзне кабатлау юлы белән яңа сүз яки форма ясау (мәсәлән: чак-чак, көлә-көлә, чаба-чаба).

РЕДУТ *и. хәрби. иск.* Кырда тирә-ягы вал һәм канау белән әйләндереп алынган ныгытма. [*Севастопольнең*] *бөтен халкы шәһәрне саклауга кутәрелгән. Ике атна эчендә шәһәр бастионнар һәм редутлар --- белән әйләндереп алынган.* СССР тарихы.

РЕЕ'СТР *и.* Милекне, әйберләрне хисапка алу максаты белән төзелгән язма исемлек. || Эш кәгазьләрен, документларны һ. б. теркәү, язып бару өчен кенәгә.

РЕЖИМ *и.* 1. Дәүләт төзелеше; дәүләт белән идарә итү формасы. *Халык-демократия режимы.* □ [*Хөрмәтулла:*] *Немец бит ул хәйлә корып маташа.. Үзенчә иске режимның кайтуын өмет итә.* Т. Гыйззәт.

2. Эштә, хезмәттә, мәктәптә, көндәлек тормышта һ. б. ш. төгәл билгеләнгән тәртип. *Ашау режимы.* □ *Мусаның гадәтләнгән, бер дә бозмыйча саклый торган көндәлек эш режимы бар иде.* Р. Мостафин. *Йөрәгегез таушала төшкән. Ләкин режим саклаганда, бу йөрәк белән торырга була әле.* Г. Әпсәләмов.

3. Теге яки бу максат өчен үтәлүе кирәк булган кагыйдәләр, чаралар системасы. *Куркынычсызлык саклау режимы. Яшелчәләрне саклау режимы.* □ *Учак ягып җибәрсәләр дә яхшы булыр иде, әлеге дә баягы, ярамый, Идел сугыш режимына буйсындырылган.* Г. Гобәй.

4. Берәр нәрсәнең эш, эшчәнлек, яшәү шартлары. *Үсемлекләрнең җылылык режимы.* □ [*Николай*] *бораунының эшләү режимы хакында журналдан яңа фикерләр эзләп тапты.* И. Гази.

РЕЖИМЛЫ *с.* Режим (2, 3 мәгъ.) белән алып барыла торган; режимга буйсындырылган. *Режимлы хезмәт. Режимлы ял.*

РЕЖИМЛЫЛЫК *и.* Режимлы булу.

РЕЖИССЁР *и.* Спектакль һәм кинофильмнар куюга җитәкчелек итүче; драма әсәрен сәхнәгә куярга әзерләүче. *Репетицияләр таңга кадәр сузыла, артистлар, уеннарын режиссерга ошата алмыйча, маңма тиргә баталар.* Г. Бәширов. || *күч.* Гомумән нинди дә булса эштә юнәлеш бирүче, аның җитәкчесе, оештыручысы. *Бүгенге кичәнең җитәкчесе — үзенә күрә режиссеры булуым мине беразга айныттты.* М. Әмир.

РЕЖИССЁРЛЫК *и.* Режиссер вазифасы, режиссер эшчәнлеге. *Режиссерлык итү.* || *с. мәгъ.* Режиссерлыкка бәйләнешле. *Әлегә [Г. Камалның] артистлык һәм режиссерлык иҗаты ныклап тикшерелеп бетмәгән.* Сов. әд.

РЕЖИССУ'РА *и.* 1. *к.* режиссерлык.

2. Спектакльне, фильмны куюга җитәкчелек.

3. *җый.* Спектакльне, фильмны куюга җитәкчелек итүчеләр; режиссерлар.

РЕЗЕДА *и.* Башак сыман вак чәчәк ата торган исле үлән үсемлек (ак чәчәкле, хуш исле бер төре бакчада үстерелә). *Ясмин чәчәкләре, резедалар китерегез миңа!* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Шул үсемлекнең чәчәгеннән хәзерләнгән. *Резеда мае.*

РЕЗЕ'КЦИЯ *и. мед.* Организмның имгәнгән яки авырып зарарланган өлешен операция ясап кисеп алу.

РЕЗЕРВ *и.* 1. Кирәк вакытта тоту (файдалану, куллану) өчен сакланыла торган нәрсә; запас. *Производство резервлары. Азык резервлары.*

2. Яңа көчләр, средстволар чыганагы. — *Миңнегалиев буровоен тикшерәм. - - - Ул бик зур резерв тапкан.* И. Гази. *Халык хуҗалыгының өзлексез үсүе өчен материаль, финанс һәм хезмәт резервларының әһәмияте бик зур.* Политэкономия.

3. *хәрби.* Сугыш хәрәкәтләре вакытында кирәкле очракта сугышка кертү өчен командир карамагында калдырыла торган хәрби көчләр. *Кояш чыгар алдыннан „тревога" кычкырып, [солдатларны] уяттылар да, урман авызына алып чыгып, резервка куйдылар.* М. Гали. *Бер урында дошманның резервта яткан кавалерия бүлекләре, ике полк арасына килеп кереп, Нуруллиннар полкына һөҗүм итә, кысрыклый башлады.* А. Шамов. || *с. мәгъ.* Резервта (2, 3 мәгъ.) булган. *Замень-Репя авылы ике яклап кысылса да, немец командованиесе үзенең артиллериясен дә, резерв подразделениеләрен дә аннан алырга җыенмый.* Соц. Тат.

4. *хәрби.* Гаскәри хезмәтне үткән һәм кирәк булганда армиягә яңадан чакырыла торган хәрби исемлектә торучылар. — *Аңлагыз, иптәш кече лейтенант, Ватан өчен сез һәрвакытта да резервтагы ышанычлы солдат.* М. Мәһдиев.

РЕЗЕРВА'ЦИЯ *и.* Төньяк Америкада, Көньяк Африкада, Австралиядә: илдәге төп җирле халык көчләп күчереп утыртыла торган урын. *АКШта индеецлар резервациясе.*

РЕЗЕРВИСТ *и.* Кайбер дәүләтләр армиясендә: резервтагы (запастагы) хәрби хезмәткәр.

РЕЗЕРВУАР *и.* Сыекчалар, газлар саклау өчен чан, бак (савыт, урын). *Юл чатларында, борылмаларда резервуарлар, промысел вышкалары күзгә чалынгалап кала.* Г. Ахунов. *Чак кына читтәрәк — көмеш резервуарлар батареялары тезелешеп утыралар.* М. Хәсәнов.

РЕЗИДЕНТ *и.* 1. Империалистик дәүләтнең протекторатлагы вәкиле (асылда шушы протекторатның идарә итүчесе).

2. Дәрәҗәсе ягыннан посланниктан бер ранг түбән булган дипломатия вәкиле; министр-резидент.

3. Берәр илнең даими рәвештә чит илдә яшәүче гражданины.

4. Чит дәүләтнең билгеле бер районында яшерен эшли торган разведка вәкиле.

РЕЗИДЕ'НЦИЯ *и.* Хөкүмәт башлыгы, шулай ук зур административ урында эшләүчеләр урнашкан җир. *Ямәннең иң матур шәһәре Таиз санала. Элек король резиденциясе шунда иде.* Сов. әд. [*Садыйк*] *шәһәрнең хәзер коммуна кулында цкәнлеген, ләкин шул ук вакытта губернаторның да үз резиденциясендә яшәвен - - - сөйләде.* А. Расих.

РЕЗИН *и. сөйл. к.* резина. || *с. мәгъ.* Резиннан ясалган (эшләнгән). [*Кәрим Гаффарга:*] *Син хәзер резин көпчәккә кара айгырны җигәрсең.* Т. Гыйззәт. *Кемдер [Гәрәйнең] җилкәсенә резин таяк белән ныклап кына итеп суга.* А. Алиш.

РЕЗИ'НА *и.* Каучуктан (вулканизацияләү юлы белән) эшләнгән сузылмалы материал. — *Куксагыз безнең армиягә бик кирәк нәрсә, аннан резина ясыйлар.* Г. Бәширов. || *с. мәгъ.* Резина эшкәртүгә бәйләнешле. *Резина цехы.* || *с. мәгъ.* Резинадан ясалган (эшләнгән). [*Зиннәт абзый*] *машина насосы белән өреп кабарткан резина капчыкка шаккатып карап торды.* Г. Ахунов. *15 минут эчендә җыенырга, азык-корал алырга боерык бирдем дә үзем резина көймәне тикшерергә тотындым.* Ә. Айдар.

РЕЗИ'НАЛЫ *с.* Резинасы булган, резина катнаштырып эшләнгән; бер өлеше резинадан торган. [*Тукайның*] *өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында - - - шнурсыз резиналы ботинка иде.* М. Гали.

РЕЗИ'НКА *и. сөйл.* 1. *к.* резина. || *с. мәгъ.* Резинкадан ясалган. [*Егет*] *озынчарак буйлы, арык йөзле, башына каракүл бүрек, өстенә утырма якалы зур кара толып, аягына соры бурка белән резинка галош кигән.* Г. Ибраһимов.

2. *сөйл.* Язганны бетерү өчен махсус эшләнгән резина кисәге; бетергеч, бозгыч. *Кара резинкасы. Карандаш резинкасы.*

3. Резина җеп; тартканда сузылучан резина, мамык яки ефәк җепләр белән аралашкан резина җепләрдән торган тасма (бау).

4. *сөйл.* Резинадан эшләнгән галош. *Биек тауга менгән чакта резинкаларым тая.* Г. Тукай. *Уң аягымда иске резинка, сулында татар катасы.* Ш. Мөхәммәдев.

РЕЗОЛЮ'ЦИЯ *и.* 1. Утырышта, җыелышта һ. б. ш. берәр мәсьәләне тикшерү нигезендә кабул ителгән карар. *Мәсьәлә парткомиссиядә каралып үтәргә тиеш. Планы, резолюциянең проекты әзер булсын.* Г. Ибраһимов. *Президиумның күпчелеге Якуб тәкъдимен яклады һәм үзенең резолюциясен дә әйтте.* И. Гази.

2. Эш башында торучының, җитәкченең рәсми кәгазьләре, гаризаларга язып куйган боерыгы, күрсәтмәсе. — *Менә сез бу [кешегә] водокачка бирергә дип резолюция салгансыз, ә ул тагын ниндидер кушымта әйберләр бирүне сорый.* Ш. Камал.

РЕЗОНАНС *и. физ., тех.* 1. Нинди дә булса тирбәнүләр системасында тышкы көч тәэсире аркасында тирбәнүләр (тавыш, электр, механик тирбәнүләр) көчәю күренеше. *Көчәнешләр резонансы. Тирбәнешләр резонансы. Токлар резонансы.*

2. Бина стеналарының тавышны яңгыратучанлыгы; яңгыраш. *Концерт залында резонанс көчле була.*

3. *күч. кит.* Яңгыраш. *Мәскәүнең кайбер яшь язучылары үзләренә күрә кыю-кыю гына фикерләр әйткәлиләр бит. Фикерләре бөтен дөньяга резонанс ясый.* Г. Әпсәләмов.

РЕЗОНА'ТОР *и. физ., тех.* Резонанс күренешләре барлыкка китерә торган система (яки җисем). *Күләмле резонатор.* □ *Немец галиме Гельмгольц - - - һәркайсы бары бер генә тонга тавыш бирә торган махсус резонаторлар ясаган.* Физика.

РЕЗОНЁР *и.* 1. Үгет-нәсихәт укырга, фәлсәфә (акыл) сатарга яратучы (кеше).

2. *әд., театр.* Элеккеге пьеса һәм романнарда: сурәтләнә торган вакыйгаларга, шулай ук әсәрдә кат-

нашучы башка геройларга карата авторның үз мөнәсәбәтен, үгет-нәсихәтләрен чагылдырган персонаж. || *театр.* Шундый персонажлар ролен башкаручы артистның амплуасы.

РЕЗОНЁРЛЫК *и.* Үгет-нәсихәт укырга, фәлсәфә (акыл) сатарга яратучанлык.

РЕЗЮМЕ *и. кит.* Сөйләнгәннең, язылганның, укылганның төп тезисларын чагылдырган кыскача йомгак (нәтиҗә, сөземтә). *Мәкаләнең резюмесы. Докладның резюмесы.*

Резюме ясау — кыскача йомгаклау, нәтиҗә ясау (чыгару).

РЕЙ, РЕ'Я *и. махс.* Мачтада, җилкәнле судноларда туры җилкәннәрне беркетү, киерү өчен, механик двигатель белән йөртелгән судноларда антенналар кую, сигналлар күтәрү өчен хезмәт итә торган шудырмалы (күчмә) аркылы борыс.

РЕЙД I *и. махс.* Портта яки портка якын җирдә судноларның якорьда тору урыны. *Дарданеллдан соң бер тәүлек үткәч, Крит утравы күренәчәк һәм тагын бер тәүлектән соң Порт-Сәет рейдына килеп туктаячакбыз.* Сов. әд. *„Адмирал Ушаков" рейдка килеп туктауга, --- пристаньнан диспетчер килеп җитте.* С. Сабиров.

РЕЙД II *и.* 1. Дошманның тылында сугыш һөҗүмнәре алып бару максаты белән аның эчке территориясенә гаскәри көчләрнең (гадәттә, атлы гаскәрләр яки партизан отрядларының) үтеп керүе. *Нәкъ шул көннәрдә Нуруллалар кавдивизиясенең дошман гаскәрләре артына кереп ясаган мәшһүр рейды башланды.* А. Шамов.

2. Җәмәгатьчелек яки матбугат оешмалары тапшыруы буенча активистлар группасы тарафыннан көтмәгәндә ревизия ясау, тикшерү эше. *Безнең шәһәрдә вакытлы матбугатны һәм корреспонденцияләрне халыкка вакытында илтеп җиткерүне тикшерү максаты белән рейд үткәрелә.* Соц. Тат. || *с. мәгъ.* Рейд ясау өчен төзелгән, оештырылган. *Рейд бригадасы.*

РЕЙДЧЫ *и.* Рейдка (II) катнашучы.

РЕ'ЙКА *и.* 1. Юка, тар агач такта, планка яки борыс (гадәттә такта ярудан калган материал).

2. Үлчәү өчен бүлемнәре булган агач борыс, тар такта. *Кар үлчи торган рейка. Су үлчи торган рейка.* || Геодезия эшләрендә ике ноктаның чагыштырмача биеклеген билгели торган бүлемле үлчәү тактасы.

РЕЙС *и.* Пароход, самолет, автобусның һ. б. ш. билгеләнгән маршрут буенча башлангыч пунктта соңгы пунктка кадәр үткән юлы. *Самолетны рейска хәзерләү.* □ *Соңгы рейстан өенә дә кереп тормаска иде [шоферның] исәбе.* А. Гыйләҗев. *Бу шәһәрне без һәр рейста ике тапкыр күрәбез. Киткәндә ул безне озатып кала, кайткында каршы ала.* Сов. әд. || *с. мәгъ.* Билгеле бер маршрут буенча йөри торган. *Рейс машинасы.*

РЕЙСФЕ'ДЕР *и.* 1. Тушь яки сыегайтылган буяулар белән сызыклар үткәрү өчен сызым каләме.

2. Кыска карандаш кую өчен кыстыргычлы металл көпшә.

РЕ'ЙТАР *и. тар.* XVI—XVII гасырда Көнбатыш Европада, XVII гасырда Россиядә кавалерия солдаты. *Рейтар полклары.*

РЕЙТУЗ *и.* 1. Атка атланып йөргәндә кию өчен аякларга сыланып тора торган тар чалбар.

2. Хатын-кызлар яки балалар кия торган бәйләгән ыштан. *[Гөлсем апа], баланың бик керләнгән, сүтелеп киткән рейтузын алмаштырмакчы булып, чишендерә башлады.* Г. Гобәй.

РЕ'ЙХСВЕР *и.* Беренче бөтендөнья сугышыннан соң 1935 елга кадәр Германия армиясенең исеме.

РЕЙХСКА'НЦЛЕР *и.* 1945 елга кадәр Германиядә хөкүмәт башлыгы, дәүләт канцлеры. *1933 елның 30 январенда президент Гинденбург фашистик партия башлыгы Гитлерны рейхсканцлер итеп билгеләде.* Иң яңа тарих.

РЕЙХСТАГ *и.* 1945 елга кадәр Германия парламенты (1933 елга кадәр — сайланып, фашизм вакытында — билгеләп куелган). *Рейхстагка сайланган компартиянең әллә ничәшәр миллион тавыш алган чаклары да булды түгелме соң?* Ш. Маннур. *Германиянең вәкилләр мәҗлесе рейхстаг таратылды.* Урал. || Шул парламент урнашкан (аның утырышлары үткәрелә торган) бина. *Алышмадым кышкы сарайны мин, очрашмадым Ильич белән дә. Хәтерләдем ләкин ул чакларны Рейхстагка барып кергәндә.* З. Мансур.

РЕКВИЗИТ *и.* 1. *театр.* Сәхнә күренешләрен яки сәхнәне җиһазлаганда кулланыла торган (чын яки бутафорик) әйберләр (кием-салым, җиһазлар һ. б.).

2. *юр.* Документ юридик көчкә ия булсын өчен, аңарда мәҗбүри язылырга тиешле күрсәтмәләр (документның рәсмиләштерелгән урыны, вакыты, имза).

РЕКВИЗИ'ТОР *и. театр.* Реквизит (1 мәгъ.) өчен җаваплы кеше.

РЕКВИЗИ'ЦИЯ *и.* Аерым кешеләр һәм җәмәгать оешмалары милкенең дәүләт власте, сугыш вакытында — хәрби властьлар тарафыннан мәҗбүри рәвештә (хакын кайтару, түләү шарты белән) алынуы яки вавытлыча алынып торуы.

РЕКВИЗИ'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Реквизиция ясау. *Россиядә тимер юллар бөтенләй диярлек булмаган. Барлык йөкләр крестьяннардан реквизицияләп алынган олаулар белән ташытылган.* СССР тарихы.

РЕКЛА'МА *и.* 1. Файдаланучыларны, кулланучыларны, сатып алучыларны һ. б. тарту, аларның игътибарын җәлеп итү максаты белән үткәрелгән чара. *Табигый, безгә реклама кирәкми, чөнки китаплар сәүдә өчен басылмый.* Г. Ибраһимов. || Берәр кеше яки берәр нәрсә турында популярлык, шөһрәт тудыру максаты белән мәгълүмат тарату.

2. Кемнең дә булса дикъкатен юнәлтү өчен берәр кеше яки берәр нәрсә турында хәбәр, мәгълүмат бирә, игълан итә торган белдерү, плакат, афиша, вывеска һ. б. ш. *Кичәнең көне яхшы сайланган. Рекламасы тулы һәм кеше кызыктырырлык уңышлы эшләнгән.* Ш. Камал. *Кич урамга чыгу белән, сине бөтен яктан электр рекламалары чорнап ала.* Г. Гали. || *с. мәгъ.* Рекламага бәйләнешле; реклама өчен эшләнгән (булдырылган). *Реклама тактасы.* □ *Бауман урамы яшелле-кызыллы реклама утлары белән буеннан-буена балкып тора.* Г. Әпсәләмов.

РЕКЛА'МАЧЫ *и.* Реклама төзүче, ясаучы, реклама оештыручы. *Нью-Йорк --- — рекламалар шәһәре. Кая карама, реклама — кибетләрдә дә реклама, урамнарда да, телевизорда да, кинода да, газетада һәм журналларда да. Рекламачылар сайлау алды вакытларында чын мәгънәсендә котыралар.* Каз. утл.

РЕКЛАМА'ЦИЯ *и.* 1. *кит.* Дәгъва, таләп; жалоба; ризасызлык (канәгать булмауны белдерү).

2. *махс.* Товарның түбән сыйфатлы булуы сәбәпле, күргән зыянны каплауны (түләүне) таләп итеп, жалоба бирү, претензия ясау эше.

РЕКОГНОСЦИРО'ВКА *и.* 1. *хәрби.* Сугыш хәрәкәтләре башланыр алдыннан шул урынга, позицияләргә һ. б. разведка ясау эше. *Командирлар, автомашиналарга утырып, алгы сызыкка рекогносцировкага—иртәгә һөҗүм итәсе урыннары белән танышып кайтырга киттеләр.* М. Әмир.

2. *геод.* Геодезия эшләре башкарылырга тиешле урынны алдан барлап, тикшереп чыгу.

РЕКОГНОСЦИРО'ВКАЛАУ *ф.* Рекогносцировка ясау, үткәрү.

РЕКОМЕНДА'ЦИЯ *и.* Кемгә дә булса яңа эшкә яки берәр оешмага кергәндә аның эшчәнлеге һәм үзе турында язма рәвештә яисә телдән бирелгән уңай бәяләмә (характеристика). *Мөмкин тапсаң, тиз арада миңа большевиклар партиясе сафына кандидат булып керү өчен рекомендация җибәр.* Ф. Кәрим. — *Сез миңа ничә тапкыр ярдәм иттегез. Менә бу юлы да, әгәр сезнең рекомендациягез булмаса, ректор мине эшкә алыр идемени?* А. Расих.

2. Киңәш, теләк, тәкъдим; күрсәтмә. *Комиссия рекомендациясе.*

РЕКОНСТРУКТИВ *с.* Реконструкцияләүгә бәйләнешле.

РЕКОНСТРУ'КЦИЯ *и.* 1. Яхшырту, камилләштерү максаты белән нәрсәне дә булса тамырыннан үзгәртү, яңадан кору, төзү эше. *Производство зур гына. Өстәвенә, предприятиенең яңа төзелешләр, зур реконструкция алып барган чагы.* Э. Касыймов.

2. Сакланган өлешләре буенча һәм тасвирлауларга (сөйләп, язып бирүгә, сурәтләп күрсәтүгә һ. б. ш.) нигезләнеп нәрсәне дә булса яңадан торгызу, элеккеге хәленә кайтару эше. *Һәйкәлләргә реконструкция ясау.*

РЕКОНСТРУ'КЦИЯЛӘҮ *ф.* Реконструкция ясау, үткәрү. *Заводның иске өлешен реконструкцияли башладылар.* Г. Әпсәләмов.

РЕКОРД *и.* 1. *спорт.* Спорт ярышында ирешелгән иң югары күрсәткеч, нәтиҗә. *Йөзүчеләр ярышы төгәлләнде. Йөздән артык йөзүче катнашкан финал ярышында Татарстанның биш рекорды яңартылды.* Соц. Тат.

2. Хезмәтнең, хуҗалыкның берәр өлкәсендә ирешелгән иң югары нәтиҗә, уңыш. *Дөнья күләмендә рекорд биргән данлыклы хезмәт батырлары --- никадәр күп алар бездә!..* М. Максуд. *Биш көн эчендә Габитов бригадасы җиде йөз илле метр бораулап ташлады. Бу — кеше ышанмаслык рекорд иде.* И. Гази.

3. *сөйл.* Нәрсәнең дә булса иң югары дәрәҗәсе. *Чыдамлык рекорды.* □ *Белгеге таза аның, күкрәге киң, Карашында сизелә батырлык. Шушы инде — Җир шарында Рекорд алган соңгы матурлык.* Ф. Кәрим.

РЕКОРДИЗМ *и. спорт. к.* рекордчылык. *Рекордизм белән мавыгу.*

РЕКОРДИСТ *и.* 1. *к.* рекордчы 1.

2. Рекордизм белән мавыгучы спортчы.

3. Хуҗалык өчен кирәкле уңай сыйфатлары белән рекорд алган, югары күрсәткечләр биргән йорт хайваны. *Кайчакта рекордист сыерлардан туган бозауларга, рим цифры өстәп, аналарының кушаматларын бирәләр.* Сөт терлекчелеге...

РЕКОРДЛЫ *с.* Рекорд булырлык; иң югары, иң нәтиҗәле, иң уңышлы һ. б. ш. *Рекордлы тизлек. Рекордлы күрсәткеч.*

РЕКОРДСМЕН *и. к.* рекордчы.

РЕКОРДЧЫ *и.* 1. *спорт.* Рекорд куйган спортчы. *Моннан ике генә көн элек тәмамланган республика ярышларында тагын алты рекорд куелды. Шунысы куанычлы, рекордчыларның күбесе үзләренең былтыргы нәтиҗәләрен яхшырттылар.* Соц. Тат.

2. Производство эшендә иң югары нәтиҗәгә, уңышка ирешкән кеше. *Рекордчы нормасы. Рекордчы уңышы.*

РЕКОРДЧЫЛЫК *и. спорт.* Рекордлар кую белән чиктән тыш мавыгып китү, рекорд артыннан куу.

РЕ'КРУТ *и. иск.* Реформага кадәрге Россиядә ясак түләүче катлаулардан яңа алынган солдат. *Армиядә солдатлар санын арттыру өчен халыктан, хәрби йөкләмә нигезендә, рекрут җыю кертелгән.* СССР тарихы. || *с. мәгъ.* Рекрутка, рекрут алуга мөнәсәбәтле; рекрутлар кабул итү өчен билгеләнгән. [*Ак бандалар турындагы имеш-мимешләрне*] *„үз күзе белән күреп кайтучы“ларның берсе Хафизулла бабайның рекрут яшендәге улы Сәлимгәрәй булды.* Г. Минский.

РЕКРУТЛЫК *и. тар.* Рекрут булу хәле. *Рекрутлыктан котылу өчен, революцион яшьләр шәһәрләрдән урманнарга качып киткәннәр.* СССР тарихы.

РЕКТИФИКАТ *и. махс.* Ректификация юлы белән чистартылган спирт.

РЕКТИФИКА'ЦИЯ *и. махс.* Катнашмаларны аерту, чистарту, сафландыру (сыеклык турында). *Спирт ректификациясе. Ректификация процессы. Ректификация аппараты.*

Ректификация колоннасы — ректификация өчен аппарат.

РЕКТИФИКА'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Ректификация ясау. *Спиртны ректификацияләү.*

РЕ'КТОР *и.* Югары уку йорты башлыгы, җитәкчесе; шулай ук урта һәм югары дини уку йорты башлыгы. *Беркөнне [Әбүзәр абзыйны] ашыгыч рәвештә университет ректоры Бушканов янына чакыралар.* Г. Әпсәләмов.

РЕКТОРАТ *и.* Югары уку йортының ректоры җитәкчелегендәге административ-укыту идарәсе.— *Иван Ильич мәсьәләне ректорат каршында куячак һәм минем теманы планга кертәчәк.* А. Расих. || Шул идарә урнашкан бина яки бүлмәләр.

РЕ'КТОРЛЫК *и.* Ректор вазифасы, ректор эшчәнлеге.

РЕЛЕ' *и.* Билгеле бер вакытта электр чылбырын тоташтырырга һәм өзәргә тиешле автомат прибор. *Вакыт релесе. Газлы реле. Саклагыч реле. Арадаш реле.* || *с. мәгъ.* Релегә бәйләнешле; реле эшләп чыгара (җитештерә) торган. *Реле производствосы. Реле цехы.*

РЕЛИ'КВИЯ *и.* 1. Дингә ышанучылар тарафыннан кодрәтле көчкә ия дип уйланылган табыну әйбере.

2. Ядкарь, төс (истәлек) итеп аеруча кадерләп саклана торган әйбер.

РЕЛИКТ *и.* Борынгы заманнардан сакланып калган организм, әйбер, күренеш; борынгылык калдыгы. || *с. мәгъ.* Борынгы заманнардан сакланып калган, борынгылык калдыгы булган. *Реликт үсемлекләр.*

РЕЛЬЕФ *и.* 1. Яссылык өстендәге калку, кабарынкы сурәт (рәсем). *Рельефны җакетларда, күлмәк-пальтоларда --- кулланалар.* Йорт эшләре.

2. Җир өсте төзелеше. [*Студент-геологларның*] *кайберләре, үзләре туктаган урынның рельефын кәгазьгә төшерү өчен --- приборларны җиргә беркетә башладылар.* Г. Ахунов.

РЕЛЬЕФЛЫ *с.* 1. Яссылык өстендә калкып, кабарып, өскә чыгып торган. *Рельефлы карта.*

2. *күч.* Тәэсирле, мәгънәле; ачык, анык. *Рельефлы шигырь.*

РЕЛЬЕФЛЫЛЫК *и.* Рельефлы булу сыйфаты. *Кешелексез татар зыялыларының портреты һәм физиономиясе һәрвакыт Тукай тарафыннан тирән ачыклык һәм классик рельефлылык белән сурәтләнде.* **Г. Халит.**

РЕЛЬС *и.* Вагон, паровоз һ. б. тәгәрмәчләренең хәрәкәт итүе өчен шпалларга ике яклап беркетелгән тар корыч борыс. *Федотовичның командасы бер көн*

эчендә, шпаллардан баганалар тезеп, алар өстеннән рельслар сузды. Ш. Усманов. *Якында гына паровоз сызгыртуы ишетелде. Зур товар составы рельсларга тибә-тибә гөрелдәп узып китте.* А. Расих.

РЕ'ЛЬСЛЫ *с.* Рельска бәйләнешле, рельслар салынган. *Рельслы юл. Рельслы транспорт.*

РЕЛЯТИВИЗМ *и. филос.* Безнең барлык белемнәребезне дә шартлы, субъектив дип санап, чынбарлыкны объектив танып белү мөмкинлеген инкяр итә торган ялган, идеалистик юнәлеш.

РЕЛЯТИВИСТ *и.* Релятивизм тарафдары.

РЕЛЯТИВИСТИК *с.* Релятивизмга, релятивистка бәйләнешле.

РЕМА'РКА *и.* Пьеса текстында сурәтләнгән вакыйгаларга, тышкы күренешләргә, персонажларның характерына һ. б. ш. автор тарафыннан җәя эчендә бирелгән аңлатма.

РЕМИЛИТАРИЗА'ЦИЯ *и.* Коралсызландырылган дәүләтнең хәрби куәтен яңадан торгызу, яңадан коралландыру эше; *киресе:* демилитаризация.

РЕМИЛИТАРИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Ремилитаризация үткәрү.

РЕМОНТ *и.* Зарарланган (тузган, ватылган, сынган, ертылган һ. б. ш.) әйберләрне төзәтү (ямау, ялгау). *Капиталь ремонт. Агымдагы ремонт.* □ *Йорт идарәсе ремонтны язга чыккач кына ясарга уйлый.* М. Җәлил.— *Без, зур ремонт кирәк булганда, авыл хуҗалыгы машиналарын төзәттерү өчен читкә барып йөрмибез.* М. Гали. || *с. мәгъ.* Ремонтлау эшенә бәйләнешле; ремонт ясала торган (урын). [*Николаев:*] *Мин яңа гына берничә цехны йөреп чыктым. - - - Ремонт эшендә зур тоткарлык туган.* Ш. Камал.

РЕМОНТЛАҮ *ф.* Ремонт ясау. *Завод цехларында көне-төне эш кайный: снарядлар ясыйлар, бронепоездлар җыялар, иске тупларны ремонтлыйлар.* И. Гази. [*Мөршидә:*] *Хәмит җаным, шул арада безнең ремонтлыйсы машиналарның барын да ремонтлап бетерәбез, яме.* Р. Ишморат.

РЕМОНТЧЫ *и.* Ремонт ясаучы эшче, белгеч. *Ремонтчылар бригадасы.*

РЕНЕГАТ *и.* Үзенең әлекке карашларына хыянәт иткән һәм дошман ягына чыккан кеше; хыянәтче, мөртәт. *Син бөтен мәгънәсе белән революцияне, социализмны саткансың икән, син дә ренегатсың, мөртәтсең икән! Г. Ибраһимов.*

РЕНЕГАТЛЫК *и.* Ренегат булу.

РЕНЕССАНС *и.* Урта гасырлардан соң Европаның кайбер илләрендә капиталистик мөнәсәбәтләр тууга һәм фәннең, сәнгатьнең чәчәк атуына бәйле рәвештә культура һәм идеология алга киткән чор; яңарыш чоры.

РЕНКЛОД *и.* Сливаның эре, түгәрәк, сусыл, татлы төре.

РЕ'НТА *и.* **1.** *экон.* Капиталдан, милектән яки җирдән хезмәт куймыйча даими алына торган керем, табыш. *Промышленностьтагы рента. Игенчелектәге рента.* || *с. мәгъ.* Рентага бәйләнешле; рентадан килә торган. *Рента кереме.*

2. *фин.* Капиталистик илләрдә облигацияләре булган кешеләргә даими доход китереп тора торган срок-сыз дәүләт заемы.

РЕНТА'БЕЛЬЛЕ *с.* Үз чыгымнарын каплый, расходларны күтәрә торган, хуҗалык өчен файдалы; табышлы. || *рәв. мәгъ.* Үз чыгымнарын каплый, расходларны күтәрә торган итеп, файдалы итеп; табышлы итеп. *Хуҗалыкның рентабельле эшләве.*

РЕНТА'БЕЛЬЛЕК *и.* Рентабель(ле) булу. *Рентабельлек—хуҗалыкның төп күрсәткече булырга тиеш.* Соц. Тат.

РЕ'НТАЛЫ *с.* Доход китерә торган; табышлы. *Ренталы заем.*

РЕНТГЕН *и. сөйл. к.* рентген нурлары. || Рентген нурлары ярдәмендә яктырту. *Рентгеннан карамыйча, кирәкле анализлар алмыйча, каян беләсең [нинди авыру] икәнлеген?!* Н. Фәттах. || *с. мәгъ.* Рентгенга бәйләнешле. *Рентген кабинеты.* □ *Түбәнге катта рентген аппаратлары эшли башлады.* Г. Әпсәләмов.

Рентген нурлары — үтә күренмәс әйберләр аша үтеп керә алырлык кыска электромагнитик дулкыннардан гыйбарәт булган күзгә күренми торган нурлар. *Кызның кара озын керфекле күзләре рентген нурларыдай үтәли күрәдер кебек иде.* А. Расих.

РЕНТГЕНОГРА'ММА *и.* Берәр органның яки детальнең рентген нурлары ярдәмендә фотопластинкага яки пленкага төшерелгән сурәте.

РЕНТГЕНОГРА'ФИЯ *и.* Үтә күренми торган әйберләрнең эчке төзелешен рентген нурлары ярдәмендә фоторәсемгә төшерү. *Металлар рентгенографиясе.*

РЕНТГЕНОГРА'ФИК *с.* Рентгенографиягә бәйләнешле; рентгенография юлы белән башкарылган. *Рентгенографик тикшеренү. Рентгенографик анализ.*

РЕНТГЕНО'ЛОГ *и.* Рентгенология һәм рентгенотерапия буенча белгеч-врач. *Гөлшаһидә [Нурлыгаян апаны] район больницасына рентгенга алып барды һәм авыруны рентгенолог белән бергә үзе карады.* Г. Әпсәләмов. *Яңа больницага рентгенологлар бик кирәккә күрә, - - - шушы ике-өч көндә хәл итәргә ышандырдылар.* Г. Минский.

РЕНТГЕНОЛО'ГИК *с.* Рентгенологиягә бәйләнешле; рентгенология ярдәмендә өйрәнелә торган. *Рентгенологик тикшеренүләр.*

РЕНТГЕНОЛО'ГИЯ *и.* Медицинаның рентген нурларын диагноз кую һәм дәвалауда кулланыну өйрәнә торган бүлеге. || *с. мәгъ. к.* рентгенологик. *Рентгенология тикшеренүләре. Рентгенология кабинеты.*

РЕНТГЕНОСКО'ПИК *с.* Рентгеноскопиягә бәйләнешле; рентгеноскопия юлы белән тикшерелгән (өйрәнелгән).

РЕНТГЕНОСКОПИ'Я *и.* Авыруны белү яки (нәрсәнең дә булса) бозык урынын табу өчен үтә күренми торган әйберләрне рентген нурлары ярдәмендә махсус экранда карау, тикшерү. || *с. мәгъ. к.* рентгеноскопик. *Рентгеноскопия методы.*

РЕНТГЕНОТЕРАПИ'Я *и.* Рентген нурлары ярдәмендә дәвалау. *Медицинаның рентгенотерапия өлкәсендә дә авыруларны дәвалау өчен рентген нурлары күп кулланыла.* Физика.

РЕОМЮР *и.* Шкаласы (суның туңу ноктасыннан кайнау ноктасына кадәр) 80 градуска бүленгән термометр.

РЕОСТАТ *и.* Электр чылбырында токның көчен яки көчәнешен үзгәртү, тигезләү аппараты.

РЕПАРАЦИОН *с.* Репарациягә бәйләнешле. *Репарацион түләүләр. Репарацион план.*

РЕПАРА'ЦИЯ *и.* Җиңелгән илнең гаебе белән башланган сугыш китергән зыянны каплау максатында җиңүче илгә түләнә торган акча яки әйбер. *Германия сугыш өчен җаваплы итеп танылды, ул репарацияләр һәм контрибуция түләргә тиеш иде.* СССР тарихы.

РЕПАТРИАНТ *и.* Репатриация буенча чит илдән туган иленә кайткан кеше. *Уткән 45 ел эчендә дөньяның төрле почмакларыннан - - - йөз меңнәрчә әрмән кайтты. - - - Репатриантлар туган илебездә торак һәм эш белән тәэмин ителәләр.* Соц. Тат.

РЕПАТРИА'ЦИЯ *и.* Эмиграциядәге кешенең, гражданлык хокуклары алып, яңадан туган иленә кайтуы. *Язмыш аркасында бөтен дөньяга таралган әрмәннәр*

хәзер туган илләренә омтылалар. - - - Соңгы елларда репатриация аеруча көчәйде. Соц. Тат. || Сугыш аркасында чит илгә барып эләккән хәрби әсирләрнең һәм гражданнарның туган илләренә кире кайтуы.

РЕПАТРИА'ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Эмиграциядән, әсирлектән һ. б. ш. (гражданлык хокукын торгызып) туган илгә кире кайту.

РЕПАТРИА'ЦИЯЛӘҮ *и.* Репатриация үткәрү (ясау).

РЕПЕРТУАР *и.* Театрда, концерт эстрадасында һ. б. ш. башкарыла торган (драматик, музыкаль һ. б.) әсәрләр җыелмасы. *Музыкаль классиканың иң катлаулы, иң нәзакәтле репертуары да [Мәдинә] өчен һава шикелле үк зарур рух азыгына әйләнде.* Ш. Хөсәенов. *Галиәсгар Камал - - - заманында татар сәхнәсен репертуар белән тәэмин итүче драматургларның берсе булды.* Сов. әд. || Бер артистның башкара торган барлык рольләре, әдәби, музыкаль һ. б. ш. әсәрләре. *— Мәхмүт ипташ үзенең гармоненда - - - ариялар башкарачак. Аның репертуары „Галиябану“ белән „Баламишкин“ көйләреннән гыйбарәт.* Ш. Камал.

РЕПЕТИ'ТОР *и.* Кемгә дә булса берәр курсны, фәнне үзләштерүдә ярдәм итүче, өенә килеп дәресен өйрәтүче; хосусый укытучы.

РЕПЕТИ'ТОРЛЫК *и.* Репетитор булу, репетитор хезмәте. || *с. мәгъ.* Репетиторлыкка бәйләнешле. *Репетиторлык эше.*

РЕПЕТИ'ЦИЯ *и.* **1.** Спектакль, концерт һ. б. ш. өчен билгеләнгән драматик, музыкаль һ. б. әсәрләрне өйрәнү, әзерләү, алдан башкарып карау. *„Галиябану“-га кат-кат репетицияләр ясап, рольләребезне күңелдән белү дәрәҗәсенә килеп җитә яздык.* М. Әмир. *Озак вакыт үтмәде — студентлар арасында зур кичәгә хәзерлек репетицияләре башланды.* Г. Кутуй. || *с. мәгъ.* Репетициягә бәйләнешле; репетиция (1 мәгъ.) өчен билгеләнгән; репетиция өчен хезмәт итә торган.

2. *күч.* Нинди дә булса зур эш, көрәш, чыгыш алдыннан үзеңнең әзерлегеңне, көчеңне сынау өчен шуңа охшаш эшне үтәп карау.

РЕ'ПЛИКА *и.* **1.** Әңгәмәгә катнашучының сөйләүче сүзенә каршы төшеп яки җавап итеп сүз әйтүе, сүз кыстыруы. *Сәет үзе турында артык сүз кузгатмады, һаман шаяртып, вак-төяк репликалар белән безне көлдерергә тырышты.* Каз. утл. || Берәр тамаша, күренеш вакытында яки җыелыш, утырыш, киңәшмә һ. б. ш. барганда кемнең дә булса каршы сүз әйтеп урыннан кычкыруы, искәрмә ясавы. [*Җыенда Гаяз сөйләгән вакытта*] *Шәфыйк тупас тавыш белән реплика бирде: — Ул турыда сүз бармый. Пәке белән тарак турында сөйлә.* М. Әмир.

2. *юр.* Сүз барышында берәр якның каршы төшүе, ризасызлык, дәгъва белдерүе.

3. *театр.* Сәхнәдәге персонажның каршы уйнаучы персонаж сүзенә җавабы; шулай ук бер персонажның икенче персонаж сөйләр алдыннан яки нинди дә булса сәхнә күренеше алдыннан әйткән соңгы сүзләре. [*Хан*] *Алтынчәч ариясенең икенче куплетында - - - реплика ясый.* М. Җәлил. *Рольнең текстын белмәве һәм ике авыз сүзне ятлый алмавы белән үзен таныткан бер артистка - - - асрау кыз Биби роледә гадәтенчә тотлыга, тиешле репликаны бирми.* И. Рәмиев.

4. *муз.* Музыканың бер өлешен башка тавыш белән яки башка тонда кабатлау.

РЕПОРТАЖ *и.* Вакытлы матбугат һәм радио өчен көндәлек хәбәрләр җыйнау. || Көндәлек вакыйгалар турында вакытлы матбугатта язу яки радио, телевизор аша сөйләү (хәбәр итү). *Футбол ярышы турында радио аша репортаж.*

РЕПОРТЁР *и.* Газета, журнал, радио, информация агентлыгының һ. б. ш. көндәлек хәлләр, вакыйгалар турында хәбәрләр биреп торучы хезмәткәре. *Репортер үзенә кирәкле мәгълүматларны алгач, нәни патриотларны газета өчен рәсемгә төшереп алырга җыена.* Г. Гобәй. *Үзәк мәйдан шыгрым тулы: фотокоры, репортеры.* С. Сөләйманова.

РЕПОРТЁРЛЫК *и.* Репортер вазифасы; репортер эшчәнлеге. || *с. мәгъ.* Репортерлыкка бәйләнешле. *Репортерлык хезмәте.*

РЕПРЕССИВ *с.* Җәзалау, кысу, бастыру чарасы булган; репрессиягә мөнәсәбәтле. *Репрессив чаралар.*

РЕПРЕССИВЛЫК *и.* Репрессив булу сыйфаты.

РЕПРЕ'ССИЯ *и.* Җәза бирү, бастыру, кысу чарасы; җәзалау эше. [*Мирвәли:*] *Фронттагы репрессияне тылда да кулланырга уйлыйлар.* Т. Гыйззәт. *Царизм репрессияләренең бөтен авырлыгы эшчеләр оешмалары өстенә төшә иде.* КПСС тарихы.

РЕПРЕ'ССИЯЛӘҮ *ф.* Репрессия куллану, җәзалау, бастыру, кысу.

РЕПРИ'ЗА, РЕПРИЗ *и.* **1.** *муз.* Көйнең берәр өлешен кабатлау. || Шушы кабатлауның нотадагы билгесе.

2. Циркта яки эстрадада төп номерлар арасында чыгыш ясаучы сүз остасы; артист яки клоун башкара торган шаян номер.

РЕПРОДУ'КТОР *и.* Радиотапшыруларны яңгыратып ишеттерә торган аппарат. *Урам чатындагы репродуктордан моңлы җыр тавышы ишетелде.* А. Алиш. *Эшчеләр берәм-берәм репродуктор эленгән алгы мачта тирәсенә җыелалар.* С. Сабиров.

РЕПРОДУ'КЦИЯ *и.* **1.** *махс.* Полиграфия яки фотография ярдәмендә сурәтнең (рәсем, картина, сызым, басылган текстның һ. б. ш.) күчермәсен алу һәм аны күбәйтү.

2. Типографиядә басып күчерелгән рәсем, картина яки фоторәсем. *Репин рәсемнәренең репродукцияләре.* □ *Лектор эленеп куйган плакатларны, репродукцияләрне әледән-әле алыштырып тора.* М. Хәсәнов. [*Мәдинә*] - - - *алтынланган рамнардагы матур репродукцияләрне карап торды.* А. Расих.

РЕПРОДУ'КЦИЯЛӘҮ *ф.* Репродукция ясау.

РЕПС *и.* Вак сырлары, кытыршылары булган тыгыз тукыма. *Репс белән тышланган диван.* || *с. мәгъ.* Репстан тегелгән, репстан эшләнгән. *Репс лента. Репс юбка.* □ [*Идрис*] *малайларның икесенә ак репс күлмәк сатып алды.* А. Гыйләҗев.

РЕПТИ'ЛИЯ *и. зоол.* Сөйрәлүче хайван (елан, ташбака, кәлтә һ. б. ш.). *Борынгы сөйрәлүчеләр яки рептилияләр әнә шулай килеп чыккан.* Биология.

РЕПУТА'ЦИЯ *и.* Берәр кеше, берәр нәрсә турында таралган яхшы яки яман фикер. [*Яшьләрне*] *хәрәкәт башындагы вә эш эшләүчеләр дип хисаплыйбыз. - - - Аларга ул репутацияне „тарих“ - - - биргән.* Ф. Әмирхан. *Әйе,* [*Заһит та*] *гаепле. Шуның аркасында профессор каршында аның репутациясенә тап төшәчәк.* А. Расих.

РЕПУТА'ЦИЯЛЕ *с.* Репутациягә ия булган, репутациясе булган. *Яхшы репутацияле булу.*

РЕСПИРА'ТОР *и.* Сулыш алу органнарын зарарлы газлардан һәм тузаннан саклау өчен җайланма (фильтрлы маска яки ярым маска). *Ачык чуен белән руда, ташкүмер, мәрмәр чыгарганда, туфракны тырмалаганда һәм ашлык сукканда тузаннан индивидуаль саклану чаралары — респираторлар кулланыла.* Анатомия.

РЕСПУ'БЛИКА *и.* **1.** Властьның югары органнарын билгеле срокка сайлап куюга нигезләнгән дәүләт идарәсе формасы. *Социалистик республика. Бурҗуаздемократик республика. Халык демократия республикасы.* □ [*Халык*] *хөкүмәтне үзгәртү, республика ясау фикеренә төште.* Ш. Мөхәммәдев. *Кабиләләр*

белән король заманында гына түгел, республика урнашкач та бик сак эш итәргә туры килә. М. Юныс. || Идарә итү формасы шундый булган ил. *Көньяк Американың вак республикалары.* || *с. мәгъ.* Республикага мөнәсәбәтле; республикага караган. *Республика флагы.* □ *Республика властьлары килеп, Катерлардан корабка ук менеп, Юлчыларның санын саныйлар, Паспортларын алып карыйлар.* Ә. Исхак.

2. Совет Социалистик Республикалар Союзы. *Республика чиге тыныч түгел, Кузгалыгыз, Дошман безгә каршы ут ача.* Һ. Такташ. || Советлар Союзы составында мөстәкыйль идарәгә хокуклы милли-территориаль өлкә. *Союздаш республика. Автономияле республика. Милли республика.* □ *Дус халыклар семьясында Республикам тиң минем.* Ш. Маннур. *Мин, җәй буе киң республикабызның төрле почмакларында, авылларында йөреп, август аенда гына Москвага кайттым.* М. Максуд. || Шундый өлкәгә караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Республика министрлыгы. Республика промышленносте.* □ *Отпускыга чыккан көнне республика газетасы Заһид өчен әһәмиятле бер хәбәр алып килде.* А. Расих.

РЕСПУБЛИКА'НЕЦ *и.* Буржуаз республикачылар партиясенең члены.

РЕСПУ'БЛИКАЧЫ *и.* 1. Республика (1 мәгъ.) строен яклаучы; республика тарафдары. || *с. мәгъ.* Республиканы яклаган. *1939 ел башында Испаниянең республикачы хөкүмәте җиңелүгә очрады.* КПСС тарихы.

2. Республиканы (1 мәгъ.) яклап, дошманга каршы көрәшүче (сугышучы). *Ярсу белән дошман якынлаша Окопларның соңгы чигенә. Республикачылар елга аша Иске окопларга чигенә.* Ә. Исхак.

РЕССОР(А) *и.* Юл йөргәндә бәрелү-сикерүләрне йомшарту өчен экипаж, автомобиль, вагонның һ. б. ш. күчәре белән кузовы арасына куелган пружина сыман сыгылмалы җайланма (гадәттә бергә берләштерелгән берничә корыч пластинадан тора). *Автомобиль рессорлары. Винтсыман рессор. Тасмалы рессор.* □ *[Арбада] тизлек коробкасы белән бер рессора да ята иде.* М. Шәрифуллин. || *с. мәгъ.* Рессорга бәйләнешле; рессор (ясау) өчен билгеләнгән. *Рессор производствосы. Рессор корычы.*

РЕССО'РЛЫ *с.* Рессоры булган. *Юан гәүдәле бу кешенең җәй көне рессорлы читән тарантасның төренә утырган көенә --- юрга аты җай гына юыртырып барганын --- күрмәгән кеше сирәк булыр.* Ш. Камал.

РЕССО'РЛЫК *с.* Рессор ясау өчен билгеләнгән; рессор ясарга яраклы. *Рессорлык корыч.* || *и. мәгъ.* Рессор ясау өчен билгеләнгән материал. *Рессорлык сатып алу.*

РЕСТАВРА'ТОР *и.* 1. Борынгы сәнгать әйберләренә, памятникларга реставрация ясаучы белгеч.

2. *полит.* Реставрацияне (2 мәгъ.) яклаучы, реставрация тарафдары.

РЕСТАВРА'ТОРЛЫК *и.* 1. *сәнг.* Реставрацияләү (1 мәгъ.) эше.

2. Реставратор (2 мәгъ.) булу.

РЕСТАВРА'ЦИЯ *и.* 1. Бозылган, тузган, искергән нәрсәләрне (күбесенчә сәнгать әсәрләрен) элекке хәленә кайтару, яңарту эше.

2. Элеккеге, бәреп төшерелгән политик стройны яңадан торгызу, кире кайтару эше. *Берничә илдә җиңүле социалистик революция социализмның тәмам җиңүе өчен бердәнбер гарантия булып, ягъни реставрациядән гарантия булып тора.* КПСС тарихы.

РЕСТАВРА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Реставрация ясау. *Борынгы памятникларны реставрацияләү. Капитализмны реставрацияләү.* □ *Элеккеге елларда детальләрнең бер өлешен ремонт бригадалары үзләре реставрацияләделәр.* Соц. Тат.

РЕСТАВРА'ЦИЯЧЕ *и. полит. к.* реставратор 2.

РЕСТОРАН *и.* Яхшы җиһазландырылган, гадәттә музыка һәм танцылары булган кыйбатлы ашханә. *Кафесыз, ресторансыз Парижны күз алдына китерү мөмкин түгел.* Г. Гали. *[Перико:] Яңа гына ресторанның чыкканга күрәме, минем бик ук ашыйсым килми.* А. Әхмәт. || Шундый ашханә урнашкан бина. *Заһид, тирә-юненә каранып, күргән-белгән кеше юклыгына тәмам ышангач, ресторан ишеген ачты.* А. Расих.

РЕСУРС *и.* Нәрсәнең дә булса чыганагы, запасы; мөмкинлеге. *Финанс ресурслары.* □ *Колонияләрне системалы рәвештә --- талау аларны хуҗалык үсеше өчен кирәкле ресурслардан мәхрүм итә.* Политэкономия. *[План комиссияләре] районнарда хуҗалыкның үсешен тирәнтен анализларга, --- өстәмә ресурслар эзләп табарга һәм производство резервларын ачарга тиешләр.* Соц. Тат. || Акча байлыгы (запасы); яшәү чыганагы; акча доходы чыганагы.

РЕТИ'НА *и. анат.* Күзнең яктылык сизә торган эчке пәрдәсе, челтәр катлавы.

РЕТИНИТ *и. мед.* Күзнең челтәр катлавы ялкынсынуы.

РЕТО'РТА *и.* Сыекчаларны куу, матдәләрне җылытып состав кисәкләргә таркалдыру (аеру) өчен хезмәт итә торган озын һәм кәкре муенлы, груша сыман савыт.

РЕТОРТАЛЫ *и.* Ретортасы булган. *Реторталы мич.*

РЕТРАНСЛЯЦИОН *с. махс.* Ретрансляциягә бәйләнешле. *Ретрансляцион радиостанция.*

РЕТРАНСЛЯ'ЦИЯ *и. махс.* Тапшыруларны көчәйтү һәм аларны ераклыкка дөрес җиткерү өчен элемтәара пунктта трансляция тапшыруларын кабул итү.

РЕТРАНСЛЯ'ЦИЯЛӘҮ *ф. махс.* Ретрансляция ясау (үткәрү).

РЕТРОГРАД *и. кит.* Прогресс дошманы, реакционер. || *с. мәгъ.* Бик нык артта калган кара фикерле, прогресска каршы (кеше).

РЕТРОГРАДЛЫК *и. кит.* Ретроград булу.

РЕТРОСПЕКТИВ *с. кит.* Үткәннең тарихын күзәтүгә багышланган. *Мәсьәләне ретроспектив яктырту.*

РЕТРОСПЕ'КЦИЯ *и. кит.* Ретроспектив обзор; үткәнне күзәтү эше.

РЕ'ТУШЬ *и.* Фотографик позитив, негатив яки диапозитивтагы һәм басманың барлык төрләрендә оттисклардагы сурәтләрне (буяп) эшкәртү, алардагы кимчелекләрне бетерү; шулай ук гравюра тактасындагы бозылган, кырылган урыннарны төзәтү эше.

РЕ'ТУШЬЛАУ *ф.* Ретушь ясау. *Кеше карточкага төшә, негативны ретушьлыйлар. Җыерчыклар шомара, чибәрләнә кеше.* Ш. Галиев.

РЕ'ТУШЬЧЫ *и.* Ретушь ясаучы белгеч.

РЕФА'КЦИЯ *и. махс.* 1. Товарның (ачып, кибеп яки башка юллар белән) кимүе яки бозылуы сәбәпле сәүдә килешүләре вакытында аның бәясенә яки авырлыгына ташлама (скидка) ясау. || Товарның сыйфаты килешү вакытында билгеләнгәннән түбән булган очракта, тапшырыла торган товар бәясенә яки авырлыгына ташлама ясау.

2. Товарның авырлыгы зур булганда, махсус килешүләр буенча йөк озатучыга түләү өчен, тарифка ташлама ясау.

РЕФЕРАТ *и.* 1. Гыйльми хезмәт, укылган китап һ. б. ш. эчтәлеген кыскача язып яки сөйләп бирү. — *Мин рефератны быел яңадан эшләргә уйлаган*

идем,— диде Гөлнур,— мөмкин булса, киңәшегезне әйтсәгез иде. Г. Ахунов.

2. Берәр темага әдәби яки башка чыганаклардан файдаланып ясалган доклад. [*Утырышта*] *берәр яңа әйбер укыйлар яки кемнең дә булса докладын, рефератын тыңлыйлар.* Г. Әпсәләмов.

РЕФЕРАТИВ *с.* Эчтәлеге реферат формасында бирелгән. *Реферативлы журнал.*

РЕФЕРАТЧЫ *и. к.* референт 1. [*Нигъмәт казый*] *Госманның рефераты бетәр-бетмәс --- Госман янына килде дә рефератчының кулын кат-кат кысты.* Г. Ибраһимов.

РЕФЕРЕ'НДУМ *и.* Аеруча мөһим дәүләт мәсьәләләрен хәл иткәндә, аның турында бөтен халык фикерен исәпкә алу, аны бөтен халык карамагына тавышка кую. [*АКШта*] *штатларда референдум кабул итү таләпләре куела.* Яңа тарих.

РЕФЕРЕНТ *и.* **1.** Реферат укучы кеше.

2. Мәгълүм бер төр мәсьәләләр буенча даими докладчы, консультацияләр биреп торучы хезмәткәр.

РЕФЕРЕ'НЦИЯ *и.* **1.** Элеккеге хезмәте турында справка; отзыв, рекомендация.

2. Капиталистик җәмгыятьтә берәр фирманың яки шәхеснең кредит түләү мөмкинлеге турында белешмә язуы.

РЕ'ФЕРИ, РЕФЕРИ' *и.* Спорт ярышларында судья.

РЕФЕРИЛЫК *и.* Спорт ярышларына судьялык итү; рефери булу.

РЕФЛЕКС *и.* **1.** *физиол.* Хайван организмында үзәк нерв системасының катнашы белән тышкы тәэсирләргә, ярсытуларга җавап реакциясе.— *Кеше, биологик объект буларак, туганнан үлгәнгә кадәр хөрлеккә ашкына. Ул аның канында, ул шартлы рефлекс кына түгел, ул инстинкт.* А. Расих. || Берәр тышкы сәбәп аркасында белештермичә, ихтыярсыз (машиналы) ясалган хәрәкәт. *Авылның исемен ишетү белән миндә рефлекс эшли башлый.* Н. Фәттах.

2. *күч. кит.* Берәр нәрсәнең нәтиҗәсе, чагылышы, тәэсире, берәр күренеш тарафыннан барлыкка китерелгән икенче төрле күренеш.

3. *сөйл. к.* рефлексия.

РЕФЛЕ'КСИЯ *и. кит.* Икеләнүләр, шик-шөбһәләр белән тулы фикер йөртү; үз кичерешләрен, хисләрен һәрьяклап тикшерергә һәвәс булу.

РЕФЛЕКТИВ *с. кит.* Ихтыярсыз, ирексез; белештермичә, ирексездән эшләнә торган; рефлектор. *Рефлектив хәрәкәтләр.*

РЕФЛЕКТОМЕТР *и.* Яктылык кайтарылу коэффициентын үлчәү приборы.

РЕФЛЕ'КТОР *и.* **1.** Яктылык нурларын кайтара торган батынкы көзге; яктылык кайтаргыч. *Лампага рефлектор кую.* □ *Танецлар вакытында биючеләр, төрле төстә рефлектор белән яктыртылып, хосусый бер нәфасәт кәсеп иттеләр.* Ф. Әмирхан.

2. Рефлекторлы электр лампочкасыннан торган җылыткыч прибор.

3. Батынкы көзгеле телескоп.

РЕФЛЕКТО'Р *с. физиол.* Рефлекска (1 мәгъ.) бәйләнешле; тышкы тәэсирләргә, ярсытуларга белештермичә, ихтыярсыз реагирлау. *Рефлектор реакция. Рефлектор хәрәкәт.*

РЕФО'РМА *и.* Нәрсәне дә булса үзгәртү, үзгәртеп кору. *Акча реформасы. Орфографиягә реформа ясау.* || Яшәп килүче стройның нигезләрен бозмыйча, аңа политик үзгәрешләр кертү эше. *Россияне каплаган зур революция аркасында татар мәдрәсәсе, татар шәкерте дә хәрәкәткә килде, реформалар өчен көрәш башланды.* Г. Ибраһимов. *Кәбир әфәнде үзе дә реформаларга каршы түгел һәм аның мөдәррис атасы да улының фикере белән бик исәпләшә иде.* Ә. Фәйзи. || *с. мәгъ.* Реформага бәйләнешле. *Реформа чоры. Реформа проекты.*

РЕФО'РМАЛАУ *ф. к.* реформалаштыру. [*Исмәгыйль Гаспринский һәм аның фикердәшләренең*] *„тәрәккый пәрвәрлеге" борынгы дини мәдрәсәләрне реформалау, милләтне европалаштыру, яңача укуны яклаудан ерак китмәде.* М. Җәлил.

РЕФО'РМАЛАШТЫРУ *ф.* Реформа кертү (үткәрү). *Динне реформалаштыру.*

РЕФОРМА'ТОР *и.* Берәр өлкәгә реформа(лар) кертүче; үзгәртеп коручы. [*К. Насыйри*] *бездә татарның беренче реформаторы булып калды.* Г. Ибраһимов.

РЕФОРМА'ТОРЛЫК *и.* Реформатор булу. *Реформаторлык омтылышлары.* □ *Бу — XIX йөздә башланган мәгърифәтчелек һәм реформаторлык идеяләренең яңа бер баскычы, киңрәк колач ала баруы иде.* Г. Халит.

РЕФОРМА'ЦИЯ *и. тар.* XVI йөздә Көнбатыш Европада феодализмга, католик диненә һәм папа хакимлегенә каршы дини көрәш төсен алган иҗтимагый-политик хәрәкәт.

РЕФОРМАЦИОН *с. тар.* Реформациягә бәйләнешле. *Реформацион идеяләр.*

РЕФО'РМАЧЫЛЫК *и. к.* реформизм.

РЕФОРМИЗМ *и.* Эшчеләр хәрәкәтендә революцион сыйнфый көрәшне, социалистик революцияне һәм пролетариат диктатурасын инкяр иткән һәм буржуазия белән хезмәттәшлектә капитализмның нигезенә кагылмый торган өлешчә реформалар үткәрү политикасы белән чикләнгән, марксизмга дошман агым. || *с. мәгъ.* Реформизмга бәйләнешле. *Реформизм программасы.*

РЕФОРМИСТ *и.* Реформизм тарафдары.

РЕФОРМИСТИК *с.* Реформизмга бәйләнешле. *Реформистик теория. Реформистик практика. Реформистик партия.*

РЕФОРМИСТЛЫК *и.* Реформист булу. || *с. мәгъ.* Реформистлыкка бәйләнешле. *Реформистлык тактикасы.*

РЕФРАКТО'МЕТР *и.* Төрле җисемнәрдә нурлар сыну күрсәткечләрен үлчәү приборы.

РЕФРА'КТОР *и.* **1.** Күк җисемнәре сурәтләрен линзалар ярдәмендә күрсәтә торган телескоп. *Рефракторны айга юнәлтү.*

2. *иск.* Яктылыкны көчәйтә торган зурайткыч пыяла; шундый пыяла куелган лампа. *Рефрактор белән яктырту.*

РЕФРАКЦИОН *с. физ. астр.* Рефракциягә бәйләнешле. *Рефракцион күренешләр.*

РЕФРА'КЦИЯ *и. физ.* Атмосферада яктылык нурларының сынуы аркасында, ерактагы предметларның урыннарыннан авышкан булып яки формалары үзгәргән кебек күренүе. || *астр.* Җир атмосферасында нурлар сынуга бәйле рәвештә, күк җисеменең урыныннан авышкан төсле күренүе.

РЕФРА'КЦИЯЛӘНҮ *ф. физ. астр.* Нәрсәнең дә булса рефракция күренешенә керүе.

РЕФРЕН *и.* **1.** *әд.* Шигырьдә яки җырда һәр куплеттан соң кабатланып килә торган шигырь юлы яки строфасы; кушымта. *Шагыйрь: әһле хөррият, тагын кузгалыгыз! Баш күтәрмәк була дошманыгыз... — дигән ике юлны, рефрен итеп, кабатлап китерә.* Х. Хисмәтуллин.

2. *муз.* Куплет формасындагы вокаль әсәрнең үзгәртелмичә кабатлана торган кисәге (өлеше), кушымта.

РЕФРИЖЕРА'ТОР *и.* **1.** Суыткыч машинаның сыекчаны парга әйләндереп, түбән температура бирә

торган өлеше. || *с. мәгъ.* Рефрижераторга бәйләнешле. *Рефрижератор җайланмасы.*

2. Тиз бозылучан азык-төлек ташу өчен суыткыч машина(лар) куелган судно, вагон, автомобиль һ. б. ш.

РЕФРИЖЕРА'ТОРЛЫ *с.* Рефрижераторы булган. *Рефрижераторлы судно. Рефрижераторлы вагон.*

РЕЦЕНЗЕНТ *и.* Рецензия авторы. *Рецензент бәяләмәсе.* || Рецензияләр язу белән махсус шөгыльләнүче тәнкыйтьче. *Журнал рецензенты.* □ *Тәнкыйтьче - - - бер мәкаләсендә Ян Винецкийның - - - романын каты гына тәнкыйть итеп чыккан иде. Рецензент, бәлки, мавыга төшкәндер. Ләкин - - - асылда ул хаклы.* Сов. әд. || *с. мәгъ.* Рецензентка бәйләнешле; рецензент өчен билгеләнгән. *Рецензент эшчәнлеге. Рецензент гонорары.*

РЕЦЕНЗЕНТЛЫК *и.* Рецензент булу.

РЕЦЕ'НЗИЯ *и.* Фәнни хезмәтне, әдәби әсәрне, спектакль, концерт, кинофильмны һ. б. ш. тикшереп, аңа язма рәвештә бирелгән бәяләмә. Шундый бәя биреп язылган тәнкыйть мәкаләсе. *Закир Һади әфәнденең „Яңа әсхабе кәһаф" исемле әсәренә кечкенә генә бер рецензия язган идем.* Ф. Әмирхан. *Икенче биттә өлкә газетасы ниндидер авторның татар телендә басылган зур прозаик әсәренә рецензия биргән иде.* А. Расих.

РЕЦЕ'НЗИЯЛӘҮ *ф.* Берәр нәрсәгә (әдәби әсәр, фәнни хезмәт һ. б. ш.) рецензия язу, бәяләмә бирү; берәр нәрсә турында үз фикереңне, бәяңне язып бирү. *Спектакльне рецензияләү.*

РЕЦЕПТ *и.* Аптекадан алу өчен даруның составы һәм аны хәзерләү, авыруга ул даруны ничек куллану турында күрсәтеп, врач язып биргән рәсми кәгазь. [*Лутов:*] *Авыруны ныклап тикшерми торып, аңа рецептлар язуның мәгънәсе юк.* Ш. Камал. [*Врач*] *рецепт кәгазенә берничә сүз сызгалап бирде.* Г. Гобәй. || Берәр нәрсә (ашамлык, әремә, катнашма һ. б. ш.) хәзерләү ысулы. *Чәкчәк рецепты. Сыра кайнату рецепты. Пыяла әретү рецепты.* || *күч. сөйл.* (Теге яки бу очракта ничек эш итәргә кирәклеккә) киңәш, күрсәтмә, белешмә. *Бер язучыга да - - - туры бер рецепт биреп булмый.* Һ. Такташ. *Бездәге әсәрләрдә зур җитешсезлекләрнең берсе — - - - бөтен типларны бер әсәрдә бирергә омтылудан гыйбарәт. - - - „Кандыр буе"ның кешеләре, чынлап карап чыкканда, нәкъ менә шул рецепт белән төзелгән.* М. Җәлил.

РЕЦЕПТАР *и.* Врач рецептлары буенча даруларга заказлар кабул итеп торучы аптека хезмәткәре. *Рецептар - - - Бибиҗамал апаның рецептын карап чыкты да бер җиренә кызыл карандаш белән сызды.* Ш. Хөсәенов.

РЕЦЕ'ПТОР *и. физиол.* Сизү нерв җепселләренең ярсытулар тәэсиренә бирелүчән очлыгы (оч өлеше).

РЕЦЕПТУ'РА *җый и. мед.* Дару хәзерләү һәм дару рецептын дөрес язу буенча кагыйдәләр җыелмасы. || Берәр нәрсәне (ашамлык, әремә, катнашма һ. б. ш.) хәзерләү буенча мәгълүматлар, белешмәләр, күрсәтмәләр җыелмасы. *Ислемай рецептурасы. Ашламалар рецептурасы.* □ [*Габбас:*] *Иптәшләр, табигатьтә иң матур төсләр комбинациясен чагылдыра торган яңа рецептура ачтым. Менә формуласы!* Ш. Камал. || *с. мәгъ.* Рецептурага бәйләнешле. *Рецептура китабы. Рецептура белешмәләре.*

РЕЦЕ'ПЦИЯ *и. кит.* Берәр җәмгыятьнең башка илдә яки башка дәвердә барлыкка килгән культура һәм социологик формаларны кабул итүе һәм үзләштерүе. *Хокук рецепциясе.*

РЕЦИДИВ *и.* **1.** Нәрсәнең дә булса яңадан кабатланулы. || *мед.* Бөтенләй бетте дип уйланылган авыруның яңадан башлануы.

2. *юр.* Моңа кадәр җинаять өчен җәза срогы үткән кешенең яңадан шул ук җинаятьне кабатлавы яки икенче бер җинаять эшләве.

РЕЦИДИВИСТ *и.* Берәр җинаять эшләве өчен җәза срогын үткәннән соң кабат җинаять ясаучы кеше. *Рецидивистның яңадан хөкемгә тартылуы.*

РЕЧИТАТИВ *и. муз.* Гадәттә операда ритмик ирекле фразаларны кулланыга нигезләнгән, үзенең интонацияләре белән нәфис сүзгә якын торган вокаль-музыкаль форма; көчле декламация; сөйләгән кебек җырлау. *Мин монда бер мәсьәләгә тукталдым: либретто музыкага салу өчен уңайлымы дигән мәсьәлә, речитативлар күп түгелме, - - - дуэтлар һәм ариялар озын түгелме һ. б.* М. Җәлил. *Урам уртасында ап-ак чәчле кеше бәет әйтә.— Урыны белән бәет көйләп сузыла, урыны белән сүзләр җитез речитатив рәвешендә бер-берсен куып ашыгалар.* Сов. әд.

РЕЧЬ *и. к.* чыгыш. *Юбилей рече. Прокурор рече. Тәбриклү рече.* □ *Карт полковник дсфәндияровның кыска гына реченнән бары өч-дүрт сүзе генә ишетелеп калды.* Ш. Камал. *Хуҗалар тәкъдим итмәс борын ук, рюмканы кулыма алдым һәм - - - ялкынланып багышлау рече сөйли башладым.* М. Әмир.

РЕЭВАКУАЦИОН *с.* Реэвакуациягә бәйләнешле. *Реэвакуацион комиссия.*

РЕЭВАКУА'ЦИЯ *и.* Эвакуацияләнгән халыкны, учреждениене, предприятиене һәм аларның милкен элекке урыннарына кире кайтару.

РЕЭВАКУА'ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Эвакуациядән кайту.

РЕЭВАКУА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Реэвакуация ясау (үткәрү).

РЕЭ'КСПОРТ *и.* Чит илдән кертелгән товарны башка илләргә чыгару (сату).

РЕЭМИГРАНТ *и.* Эмиграциядән туган иленә кире кайткан (яки кайтарылган) кеше.

РЕЭМИГРА'ЦИЯ *и.* Эмигрантларны туган илләренә кире кайтару эше.

РЕЭМИГРА'ЦИЯЛӘНҮ *ф.* Эмиграциядән кайту.

РЕЭМИГРА'ЦИЯЛӘҮ *ф.* Эмиграциядән кайтару.

РИАЛ *и.* Иранда акча берәмлеге.

РИАЛАНУ *ф. к.* риялану. *Бернича татар, риаланып, губернаторга барып йөрделәр йөрүен.* Ш. Камал.

РИАЛЫ *с. к.* риялы.

РИАЛЫЛЫК *и. к.* риялылык.

РИВАЯ *и. иск. к.* риваять.

Ривая кылу (итү) — *к.* риваять кылу (итү).

РИВАЯТЬ *и.* Борынгылардан, буыннан-буынга сөйләнеп (күчеп) килгән хикәя, тариx. *Моратай - - - заманында бик гаярь, бик дан кеше булган имеш дигән риваять йөри.* Г. Бәширов. *Риваятьләрнең раславына караганда, икс яшь йөрәк [Адәм белән Һава], Сак белән Сок кебек, икесе икс якта бер-берсен күрергә зар-интизар булып, нәкъ икс йөз ел тилмерешеп йөриләр.* Г. Гобәй. || Әкият, уйдырма. *Кайчак сезнең агай-эне, Хәйдәр, кеше күңеле караңгы дип язарга ярата. Минемчә, бу риваять бик борынгы.* Г. Әпсәләмов.

Риваять итү (кылу) — борынгылардан, буыннан-буынга күчеп килгән хикәяне, тарихны сөйләү (сөйләп бирү); сөйләү, хикәяләү. [*Бу хайванның*] *бер-бер җан иясенә - - - һөҗүм итеп тә, аз гына да булсын җәрәхәтле алганын риваять итмиләр.* Г. Тукай. *Бездә — татарларда - - - әкият вә җырлар булганнар вә - - - халык арасында хәзергә кадәр риваять ителеп киләдер.* Ф. Әмирхан.

РИВАЯТЬЧЕ *и.* Риваять сөйләүче.

РИГАЯ *и. иск.* Игътибар; әһәмият. *Башка дәреслəр турысында ясала торган ригая рус әдәбияты вә*

аның тарихы дәресләрендә һичбер ясалмый. Ф. Әмирхан. || Ихтирам; хөрмәт, мәрхәмәт; яхшы мөгамәлә, әдәп. [*Мәүлиха түтинең*] *соргылт күзләрендә һәм шактый озынча ябык битендә аны тыңлаучыга да, ул телгә алган бүтән кешеләргә дә яхшы теләк һәм ригая яктысы балкып тора иде.* Г. Бәширов.

Ригая кылу (итү) — 1) игътибар итү, әһәмият бирү; 2) ихтирам итү, хөрмәт итү, яхшы мөгамәләдә булу; әдәп саклау. [*Бәдигылҗамал Ибраһимга:*] *Дөньяда бер хатын белән генә эш бетми. Ара-тирә аны да ригая кылырга кирәк.* Г. Камал. **Ригая күрү** — хөрмәт ителү. *Инабәт белән эш итүченең таләбе ничек тә „абруй"дан төшмәү, ригая күрү.* Г. Тукай. **Ригая күрсәтү** — хөрмәт итү (күрсәтү). [*Эшчеләр*] *мине якын күрәләр, „уңган шәкерт" дип, ригая күрсәткән булалар иде.* М. Гафури.

РИГАЯЛЕ *с.* Игътибарлы; әһәмият бирүчән. || Ихтирамлы; хөрмәтләүчән; мәрхәмәтлә, рәхимле, әдәпле.

РИГАЯТЬ *и. к.* ригая. *Нәзафәткә ригаять юк, имеш бездә нә бөһтандыр! Аның чөн йорт саен берәр комганыбыз бардыр.* Г. Тукай.

РИДИКЮЛЬ *и.* Акча, ачкыч, тарак, күзлек, кулъяулык һ. б. ш. вак-төяк әйберләр салу өчен хатынкыз сумкасы. *Магазинга җиткәч* [*Рәйханә*] *ридикюлен актарып, - - - акчаларын барлады.* А. Расих. *Дина, ридикюлендәге кечкенә көзгегә карый-карый, чәчен-башын тәртипкә китерде.* С. Рафиков.

РИ'ЗА *и.* Чиркәү руханиеның гыйбадәт вакытында кия торган киеме. *Манифестациянең башында алтынланган атлас ризалар кигән озын чәчле поплар килә.* А. Расих. || Мәскәү патшаларының алтын һәм көмеш белән зиннәтләп бизәлгән бәйрәм киеме.

РИЗА[1] *хәб. сүз.* 1. Канәгать, канәгать булу. *Гөлшаһидә Акъярыннан риза иде.* Г. Әпсәләмов. *Халык шуңар да риза.* [*Сәлимнең*] *сүзләрен кул чабып каршыладылар.* Г. Гобәй.

2. Нәрсәгә дә булса ризалык бирү, карышмау, каршы килмәү. [*Өйләнешүгә*] *минекеләр дә, Гайнияекеләр дә ризалар иде.* Г. Ибраһимов. *Мин иң авыр җәзаларны да күтәрергә риза.* Ә. Айдар.

Риза булу — 1) берәр эш эшләргә, үтәргә күнү, карышмау, каршы килмәү. *Секретарь башта язмаска да булган иде, ләкин бик үтенгәч, риза булды.* А. Шамов; 2) булганына канәгатьләнү, артыгын таләп итмәү. — *Барына риза булып торган булабыз.* М. Гафури.

РИЗАЛАНДЫРУ *ф. к.* ризалату. [*Күчәрбайны волостька барырга*] *чак ризаландырдым бит.* М. Әмир.

РИЗАЛАНУ *ф.* 1. Булганы белән чикләнү, канәгать булу, артыгын таләп итмәү. *Халыкъның болай иренмичә төшендереп сөйләвенә Галләмнең күңеле бик ризаланды.* Ш. Камал.

2. Берәр шартка килешү, риза булу, күнү. *Хафиз, - - - сүз көрәштереп бу хатынны җиңеп булмаячагын бик нык төшенгән хәлдә, ярым ризаланган булып, сүзне өзәргә теләде.* Ә. Фәйзи.

РИЗАЛАТУ *ф.* 1. Кемне дә булса канәгатьләндерү, канәгать итү.

2. Кемне дә булса берәр нәрсәгә күндерү, ризалыгын алу. [*Дсма белән*] *бергә булырбыз әле дип өметләнә идем. Тик әнкәйне генә ризалату авыр иде.* Г. Ибраһимов. [*Васил*] *әнисен үз янына торырга чакырса да, ризалата алмады.* С. Рафиков. || Бурычлы булып калмау, кем белән дә булса алыш-биреш мәсьәләсендә араны өзү.— *Уем — тиңсез матур алманың иясен* [*кызны*] *ризалату иде.* М. Фәйзи.

РИЗАЛАШУ *ф.* 1. Бер-берсе белән уртак фикергә килү, килешү. *Эш ул дигәнчә барып чыкмаслыгын аңлагач, врачлар тәкъдиме белән ризалашырга мәҗбүр булды.* Р. Төхфәтуллин. || Ризалык бирү, риза булу. *Егет үзе белән барырга бик кыстаса да, Луиза ризалашмады.* А. Гыйләҗев.

2. Канәгатьләнү, ризалык белдерү. *Акча алганда байтагысы ризалашмый, расходын күпсенә, Гарифка ышанмый, көйсезләнә, икенче, өченче кат саната иделәр.* Ш. Камал.

РИЗАЛЫК *и.* Риза булу хәле. *Кызчыкның башын иеп ризалык белдерүен күргән Фатыйма гаҗәпләнмичә кала алмады.* Г. Минский. *Әгәр дә Буранбай риза булмаса,* [*Газинур*] *аның ризалыгын көч белән тартып алырга да хәзер иде.* Г. Әпсәләмов.

Ризалык алу — күндерү; рөхсәт алу. *Гөлсем апа, иреннән ризалык алгач, Маратны ул итү белән генә чикләнмәскә булды.* Г. Гобәй. **Ризалык бирү** — риза булу, күнү; рөхсәт итү.— *Маликка үч итеп, сайланырга ризалык бирәм, сайлагыз мине!* — *дип әйткән* [*Миңнулла*]. И. Гази. **Ризалык юк** — риза түгел, рөхсәт юк.— *Карагыз, сез дә анда кеше артыннан сайлау эшләренә катыша күрмәгез тагын, минем һич ризалыгым юк.* Ш. Мөхәммәдев.

РИЗАЛЫКСЫЗ *рәв.* Рөхсәтсез; үзара килешмичә, аңлашмыйча. *Фәхригә ризалыксыз чыккангa, Гайшә моңарчы ата-анасы белән йөрешми иде.* Г. Ибраһимов.

РИЗАСЫЗ *с.* Риза түгел, канәгатьсез. *Ул нинди-дер ачулы һәм ризасыз тавыш белән сүзен дәвам итте.* С. Рафиков.

РИЗАСЫЗЛЫК *и.* Риза булмау тойгысы, канәгатьсезлек, килешмәүчәнлек. *Халык арасында ризасызлык башланды.* М. Гали. *Мин тапкан юалык шәп иде дип, Вафа ризасызлык биреп куйды.* Ә. Фәйзи.

РИЗЫК *и.* Ашау-эчү өчен азык булып хезмәт итә торган нәрсә; ашамлык, азык. *Ризык ташыйлар кошлар басудан.* Г. Тукай. *Киң балконлы тын бүлмәләр анда, Ризык белән тулы өстәлләр.* Ш. Маннур. || Гомумән ашау-эчүгә муллык турында. *Сезнең дә - - - кешеләр төсле мул тормыш, киң ризык белән гомер итүегезне күрәсем килә.* Ә. Еники.

Ризык бетү (киселү) — 1) яшәү шартлары начарлану, килере бетү, азык табу юлы киселү. *Шырпы фабрикасы тарафыннан боларның ризыгы киселде.* М. Гафури; 2) карт буын теләндә: гомернең чигенә җитү, үлемгә җитү, яшәү вакыты бетү.— *Кешенең кайбар ризыгы бетмәгән булса, Гандәлип түти, ис итмәгәндә килә дә чыга бит.* Ш. Камал. **Ризык тарту** — кая да булса күчеп китүне тәкъдир, язмыш, ашыйсы ризыгы булу дип, хорафатка ышанучыларча караудан туган тәгъбир. — [*Себергә*] *кеше үзе китми ул, аны ризык тарта,— ди торган иде* [*хәзрәт*]. Г. Ибраһимов. **Ризык үтү** — аппетит булу, тамакка ашый алу, аш үтү. **Ризыктан олы түгелсең** — өстәл янына утырмаганда, тәкъдим ителгән азыктан баш тартканда әйтелә. *Мәүлиха түти* [*Нәфисәгә*] *авыз ачарга да ирек бирмәде:— дидә булгач, әйдә! - - - Ризыктан олы түгелсең!* Г. Бәширов.

РИЗЫКЛАНДЫРУ *ф.* Ашату, туендыру; ашатуэчертү. *Гүяки күп гасыр буенча ата-бабаларын ризыкландырган, хәзер үзләрен, газиз балаларын ризыкландырып килүче мөкатдәс туфракларына басты каңлы Гитлерның каңлы итеге.* Г. Гобәй.

РИЗЫКЛАНУ *ф.* Ашау-эчү, азыклану; туену. *Атна саен авылга кайтып, бер-ике арыш икмәге, - - - берике кадак ит, алты мыскал чәй алып килеп, шулар белән атна буенча ризыкланып тора идем.* М. Гафури. || Тамак туйдыру, яшәү. *Минем кеше хакы ашап ризыкланыр хәлем юк.* Ш. Камал. *Ризыкланган ачы тирләр һәм көч белән, Көн буена ташлар ватып чүкеч белән.* Г. Тукай.

РИКОШЕТ *и.* Хәрәкәттәге каты әйбернең берәр нәрсәгә бәрелгәннән соң кыек почмак ясап очышы. || *күч.* Берәр төрле урынсыз сүзнең, гаепнең нәтиҗәсез калып, әйтүченең үзенә зарар итүе, үзенә кайтуы турында. *Богдасаровның минем өскә ташлаган гаепләре барысы да рикошет белән аңа барып тиде* [*дип уйлады Гыйльманов Алмаев турында*]. И. Гази.

РИ'КША *и.* Көнчыгыш һәм Көньяк Азиянең кайбер илләрендә, Көньяк Африка союзында: зур булмаган ике тәгәрмәчле җиңел арбага җигелеп, пассажирлар һәм йөкләр йөртүче кеше. *Заһир --- Шанхай урамнарында рикшага утырып йөргән.* М. Мәһдиев.

РИМЛЫ *и.* Борынгы Рим дәүләте кешесе. *Б. э. га кадәр II гасыр урталарына таба римлылар әлекке куәтле Македонияне үзләренә буйсындырганнар.* Бор. зам. тарихы.

РИНГ *и. спорт.* Аркан белән әйләндереп алынган, бокс ярышлары үткәрелә торган кечкенә мәйдан, бокс мәйданы. *Ихтыярсыздан аның күз алдына якты зал, ак бау белән уратып алынган ринг, шаулы тамашачылар килеп басты.* Г. Әпсәләмов.

РИНОЛО'ГИЯ *и.* Медицинаның борын авыруларын өйрәнә торган бүлеге.

РИНОПЛА'СТИК *и. мед.* Зарарланган борынны пластик хирургия методы белән әлекке хәленә кайтару яки аның формасын үзгәртү.

РИНОСКОП *и. махс.* Медицинада борын-тамак куышлыгын карау өчен кулланыла торган махсус көзге.

РИСАЛӘ *и. иск. кит.* Хикәя. *Хөсәен яңа чыккан рисаләләрне укый һәм менә инде икенче ел „Тәрҗеман"ның да мөштәрие иде.* Ф. Әмирхан. *Газеталар да татарча --- языла башладылар, китап вә рисаләләр дә татарча чыга.* Г. Тукай.

РИСВАЙ *с.* Хур (мәсхәрә) ителгән, гаепләре ачылып хурлыкка төшкән. [*Гарәп:*] *Нишлик, тәхет, тажлар рисвай бүген. Нәләт! Дошманнарга мең нәләт!* Ф. Бурнаш.

Рисвай булу — мәсхәрәгә калу, яман ат(ы) чыгу, хурлыкка төшү, хур булу. [*Мавия:*] *Йөгем беленеп, Мияс мәктәбеннән куылган көннән алып шул исемне тагып рисвай булып йөрим.* М. Фәйзи. **Рисвай галәм итү** — бөтен халык алдында мәсхәрәләү, мәсхәрә итү, хурлыкка төшерү. *Икенче көн хөкем ясап, Рисвай галәм иткәннәр, Битләренә корым сөртеп, Урам буйлап йөрткәннәр.* Т. Гыйззәт. **Рисвай итү** — оятка калдыру, мәсхәрә итү, яман атын чыгару. [*Нургали:*] *Минем эшемдә кимчелекләр күрәсез икән — әйтегез, иллә мәгәр мине халык алдында рисвай итмәгез, моңарчы күрсәткән хезмәтемне юкка чыгарып ташламагыз.* Ә. Еники.

РИСВАЙЛЫК *и.* Хурлык, мәсхәрә; оятка, мәсхәрәгә калу. *Төрле рисвайлыклар баштан кичерү.* □ *Гомер буенча шундый хурлыкта, шундый рисвайлыкта, шундый газапта мәшәкать чиккәнче, үлүең мең-мең өлеш артык!* Г. Камал.

Рисвайлыкка төшү (төшерү) — *к.* рисвай булу (рисвай итү).— *Укымаган балаларның --- кайберәүләренең ата-анага күпме зыян китерүләре, ил-күз алдында аларны рисвайлыкка төшерүләре һәркайсыбызга мәгълүм.* Х. Кәрим.

РИТМ *и.* Нинди дә булса әлементларның (тавыш, сөйләм һ. б.) билгеле бер әзлеклелек, ешлык һ. б. белән чиратлашуы. *Пычкы, бер күтәрелеп, бер төшеп торган уңайга, Газинурның күз алдындагы киң кырда, карасу яшел урманда мәгълүм бер ритм белән тибрәнергә тотынды.* Г. Әпсәләмов. *Йосыповның шигырьләре әле художество, рифма, ритм ягыннан да бик кытыршылар.* М. Җәлил. || Нәрсәнең дә булса башкарылуындагы, агышындагы тизлек.— *Ритмны тигез тота белсәгез, өстәмә рәвештә елына тагын дүрт-биш мең тонна гидрат бирә алыр идегез.* Э. Касыймов. *Тормышның ритмы һәркемнең үзенчә.* М. Мәһдиев.

РИ'ТМИК *с. к.* ритмлы. *Ритмик хәрәкәт. Ритмик басым.*

РИ'ТМИКА *и.* **1.** Ритмның системасы һәм характеры. *Муса Җәлил шигырьләренең ритмикасы бай һәм үзенчәлекле.* М. Гайнуллин.

2. Ритм турында тәгълимат.

3. Ритмны сиземләү тойгысын тәрбияләү максаты белән үткәрелә торган физкультура күнегүләре системасы.

РИ'ТМЛАШТЫРУ *ф.* Нәрсәгә дә булса ритм кертү, нәрсәне дә булса ритмга нигезләп төзү. *Эш процессын ритмлаштыру. Хәрәкәтләрне ритмлаштыру.*

РИ'ТМЛЫ *с.* Ритмга бәйләнешле, билгеле бер ритмда башкарыла торган, тигез.— [*Солтанморатовның*] *йокы артерияләре тибеше ритмлы, кулдагы тамыр тибеше зәгыйфьрәк.* Г. Әпсәләмов. *Минут саен кабатланып торган бу ритмлы авазлар* [*Закир абзыйның күңелендә*] *сагыш сыман бернәрсә уята.* Г. Ахунов. *Театр* [*газета фельетоныннан*] *„Курчаклар театры" методы белән, карикатуралар методы белән, аерым ритмлы хәрәкәтләр, җырлар, такмаклар аркылы ясап бирә.* М. Җәлил.

РИ'ТМЛЫЛЫК *и.* Ритмлы булу.

РИТМОПЛА'СТИКА *и. махс.* Гәүдәнең гармоник үсеше өчен физик күнегүләр системасы.

РИ'ТОР *и. тар.* Борынгы Грециядә һәм Римда оратор һәм ораторлыкка өйрәтүче.

РИТО'РИК *с.* Риторика кагыйдәләренә нигезләнгән. || *күч.* Тасвирлауда, сурәтләүдә артык күтәренкелек, эмоциональлек, кабарынкылык белән аерылып торган. *Революциянең беренче елларындагы поэзияне бәяләгәндә аның абстракт һәм риторик булуына басым ясау гадәткә кереп киткән.* Г. Халит.

Риторик сорау — ораторлар сөйләмендәге алым: сорау формасында раслап әйтүдән гыйбарәт сөйләм әйләнмәсе.

РИТО'РИКА *и.* Сүзгә осталык теориясе; матур сөйләү, ораторлык сәнгате турындагы фән. || *күч.* Тасвирлауда артык күтәренкелек, кабарынкылык. [*М. Җәлил*] *әсәрләрендә ясалмалылык һәм ялган риторика юк.* М. Гайнуллин.

РИТУАЛ *и. кит.* **1.** Нинди дә булса дини актларны башкарганда була торган һәм аларны үткәрү формасына бәйләнешле йолалар җыелмасы.

2. Гореф-гадәт буенча килә торган яки берәр нәрсәне башкаруда кабул ителгән тәртип, церемониал.

РИТУАЛЬ *с.* Дини йола буенча үткәрелә торган. *Ритуаль бәйрәмнәр.*

РИФ *и.* Корабльләр йөреше өчен куркынычлы булган су асты кыялары.

РИ'ФМА *и.* Шигырьдә: ике яки берничә юл ахырындагы сүзләрнең аваздашлыгы, бердәй яңгыравы, охшашлыгы. *Рифма ягыннан аксаган җырлар да җыентыкта байтак очрыйлар.* М. Җәлил.

РИ'ФМАДАШ *с.* Аваздаш, бердәй яңгырашлы. *Рифмадаш тезмәләр.*

РИ'ФМАЛАНЫШ *и. әд.* Шигырьдә рифмаларның чиратлашу системасы һәм тәртибе, шулай ук рифмаларның характеры. *Иректе рифмаланыш.*

РИ'ФМАЛАУ *ф. к.* рифмалаштыру. *„Х" иптәш беренче, өченче юлларны бөтенләй рифмаламый, икенче, дүртенче юлларның рифмалары да ятышсыз.* М. Җәлил. *Тәтешкә, Тәтешкә... Эшкә... Эшкә!.. Каян килде бу сәер рифмалау?* А. Гыйләҗев.

РИ'ФМАЛАШТЫРУ *ф.* Рифма ясау өчен сүзләр сайлау; шигырь юлы ахырына тиешле сүз куеп рифма ясау; рифма итеп китерү.

РИ'ФМАЛАШУ *ф.* Үзара аваздаш булып, рифма тәшкил итү. *Талип сүзенең табип белән рифмалашуы ошап китте* [*Фәниягә*]. Ф. Яруллин.

РИ'ФМАЛЫ *с.* Рифмасы булган, рифмалардан торган.

РИ'ФМАЧЫЛЫК *и. сөйл.* Сай әүтәлекле, художество ягыннан йомшак шигырьләр язу.

РИШВӘТ *и.* Билгеле бер максатка ирешү өчен урындагы кешене сатып алу нияте белән бирелә торган акча яки әйбер. *Аланбашлар әйтмешенчә, имеш, кайчандыр Байтирәк куштаннары, землемерга бер тәпән бал белән ике сарык ришвәт биреп, Аланбашның Яурышкан иңкелен үзләренә кистереп алганнар да, бу низаг шуннан башланып киткән.* Г. Бәширов.

РИШВӘТЧЕ *и.* Ришвәт алучы кеше. *Төпле, эшлекле кеше дигән тәэсир калдырган Вәлиәхмәтов, баксаң, гап-гади ришвәтче икән!* А. Гыйләҗев.

РИШВӘТЧЕЛЕК *и.* Ришвәтче булу сыйфаты. *Мәхәллә халкы арасында иснәнеп йөргәне, ришвәтчелек өчен - - -* [*Хөсәеннең*] *Гайнулланы җаны сөймиде.* А. Расих.

РИШЕЛЬЕ *и.* Бизәкнең кырыйларын әлмәкле җөй белән эшләп, бизәк сызыклары челтәрләп тоташтырылган һәм арада буш калган тукыма кисеп алынган ажурлы чигү. *Ирекле чигүгә тамбур, ришелье, тыгыз итеп ак җептән чигү керә.* Йорт эшләре.

РИЯ *и.* Кешегә күрсәтү өчен генә эшләнгән (ихлас күңелдән эшләнмәгән) эш, икейөзлелек, ясалмалылык. *Бар да — рия, бар да — хәйлә эшләгән эшләрегез, Кеше хакын ашый-ашый калмаган инде тешләрегез.* Ш. Мөхәммәдев.

Рия сату — хәйләләп маташу, кыланган булу. [*Фазыйл Солтанга:*] *Синең алдыңда рия сатарга теләмим.* Г. Ибраһимов.

РИЯЛАНУ *ф.* Кешегә күрсәтү өчен генә эшләү, ясалма кылану, икейөзләләнү, монафикълану, ялагайлану. *Д инде рияланмыйча, эчендәген яшермичә, фольклор экспедициясеннән кайтучыларны көтте* [*егет*]. Г. Ахунов. [*Профессор*] *гомерен саф килеш, пакь килеш уздырган, - - - берәү алдында да рияланмаган.* Г. Әпсәләмов. *Мин күңелемдә булганны сөйлимен, хәзрәтләргә яхшы күренер өчен рияланып сөйләр хәлем юк.* Ш. Мөхәммәдев.

РИЯЛЫ *с.* Икейөзле, ясалма, монафикъ, ялагай. *Сүз булсын өчен генә сөйләнә торган һәм мәгънәсез, һәм риялы сүзләр төшләре алынып ташланган чикләвек кабыклары шикелле шалдыравыклы, ләкин кирәксез нәрсәдер иде.* Ф. Әмирхан. | *и. мәгъ. Риялыдан рәхим көтмә.* Әйтем.

РИЯЛЫЛЫК *и.* Икейөзлелек, ясалмалылык; монафикълык, ялагайлык. *Рәнҗүләр булса да, гафу-ризалык ихластан булмыйча, [мин аны] тик риялылык, буйсынучанлык, балалык яки уйсыз җиңеллек дип саныйм.* Г. Ибраһимов.

РИЯСЫЗ *с.* Эчкерсез, турылыклы, ихлас күңелле; чын. *Саф күңелле, риясыз дуслар, - - - балалар, - - - әшче-крестьян — бу бүләкне* [*китапны*] *кабул итәрләр дип уйлыйм.* М. Гафури. [*Шамил:*] *Ләкин, Гөлшат, минем мәхәббәтем керсез, риясыз, саф йөрәктән булачак.* Т. Гыйззәт.

РИЯЧЫ *и. сир.* Икейөзле кеше, берәр нәрсә эшләгән булып кыланучы кеше.

РО'БОТ *и.* Кеше хәрәкәтләрен хәтерләткән, катлаулы эшләр башкара торган автомат, механизм. *Коммунизмда машиналар, төрле роботлар булыр, гомумән, техника, автоматика бик нык үсәр.* Г. Мөхәммәтшин.

РОГА'ТКА *и.* Ике япьле агач кисәгенә яки чыбыкка резинка бәйләп ясалган уенчык, аткыч. *Рәфкать: „Карганы рогатка белән дә атып була, әйдә наган ясыйк“, — дип үгетли.* А. Гыйләҗев.

РОД *и. лингв.* Кайбер телләрдә исемнәрнең иркәк һәм теше (мөзәккәр, мөәннәс) затларга яки әйберләргә мөнәсәбәтен белдерә торган грамматик категория. *Әгәр бер әйбер хакында „он, этот“ дип әйтергә яраса, ул әйбер мужской род, ягъни ир токым була.* Г. Тукай.

РО'ЖА *и. мед.* Тире яки лайлалы катлауларның бик каты ялкынсынуыннан гыйбарәт йогышлы авыру.

РО'ЗА *и. бот.* Розачалар семьялыгыннан гадәттә төрле төстәге хуш исле катмарлы әре чәчәк ата торган, сабаклары чәнечкеле декоратив куак-үсемлек һәм шул үсемлекнең чәчәге. *Тәрәзә төбем роза гөл, Лента белән буйлыймын.* Җыр.

РОЗА'РИЙ, РОЗА'РИУМ *и.* Розалар үстерелә торган питомник; розалар үсә торган урын, чәчәклек. *Москвадагы үзәк ботаника бакчасының розариенда төрле-төрле формадагы һәм төрле төстәге розалардан бик зур коллекция җыелган.* Робинзон әзл.

РО'ЗАЧАЛАР *и. бот.* Роза, кура җиләге, алмагач, груша, шәфталу, слива, чия, җир җиләге һ. б. керә торган агач сыман куак һәм үлән үсемлекләр семьялыгының атамасы.

РОЗЕ'ТКА *и.* **1.** Чәй янында варенье, бал салу өчен кечкенә тәлинкә.

2. Кайбер үсемлекләрдә (мәсәлән, бака яфрагы һ. б.) төрле якка нурлар сыман таралып китеп җиргә яткан яфраклар төркеме. *Аяк астында йомырка сыман яфраклар розеткасы.* Робинзон әзл.

3. *архит.* Стена яки түшәмгә ябыштырыла торган, бер ноктадан төрле якка таралып киткән яфрак яисә чәчәк, таҗ яфракчыклары рәвешендәге бизәк.

4. *махс.* Яктырткыч, җылыткыч һ. б. төрле приборларны электр челтәренә вилка ярдәмендә тоташтыру өчен оялы җайланма. *Профессор стенадагы розеткадан папиросына ут алдырды.* М. Мәһдиев.

РОКИРО'ВКА *и.* Шахмат уенында: уен барышында бер үк вакытта король һәм ладья белән йөреш ясап, ладьяны король янына китерү, корольне аның икенче ягына сикертеп кую. *Икеләнгән пешкаларның кыйммәте берәрләп торган пешкаларныкына караганда түбән, рокировка ясагач, корольнең кыйммәте аңа кадәргедән артык була.* Уйлаучы машиналар.

РОКК *и.* Россия Кызыл Хач җәмгыяте (*русчасы:* Российское общество Красного Креста).

РОКОКО' *и.* Архитектурада һәм бизәү сәнгатендә XVIII гасыр башларында Франциядә барлыкка килгән бик катлаулы, купшы стиль.

РОКФО'Р *и. махс.* Өсте алынмаган сыер, сарык яки кәҗә сөтеннән әзерләнгән, махсус күгәртү гөмбәчекләре булган әчкелтем сыр сорты; шул сорттагы сыр.

РО'ЛИК *и. тех.* **1.** Кечкенә тәгәрмәч. *Рояльгә роликлар кую. Тимераякка роликлар кую.*

2. *махс.* Электр, телеграф чыбыкларын беркетү өчен кәтүк формасындагы фарфор изолятор.

3. *тех.* Механизмның кечкенә цилиндр яки кәтүк формасындагы әйләнә торган кисәге.

РО'ЛИКЛЫ *с.* Роликлар беркетелгән, роликлар өстенә куелган. *Роликлы тимераяк. Роликлы конвейер. Роликлы чаңгыларда йөрү.* || Роликлардан торган. *Роликлы подшипник.*

РОЛЬ *и.* **1.** Сәхнәдә, кинофильмда артист гәүдәләндергән драматик образ. *Ул баш рольне сорый, һәм, ни булса ул дип, Ибрайга баш роль бирәләр.* Г. Гобәй.

2. Спектакль барышында артист тарафыннан башкарыла торган текст. *Кат-кат репетицияләр ясап, рольләребезне күңелдән белү дәрәҗәсенә килеп җитә яздык.* М. Әмир.— *Минем роль укыйсым бар.* Ш. Камал.

3. Нинди дә булса эш, шөгыль; вазифа.— *Ничек инде бу? Производствода җитәкчелек ролен инкяр итә,— дип уйлап утырды Никитин.* С. Рафиков.

4. Кемнең яки нәрсәнең дә булса әһәмияте, эшкә яки вакыйгага катнашу яисә йогынты ясау дәрәҗәсе, керткән өлеше, хезмәте, тоткан урыны. *Кичәнең беренчелек роле Миңҗамалда иде.* Г. Ибраһимов. *1905 ел революциясе чорында --- „Мәгариф“ көтепханәсенең роле бик киңәя.* М. Гали.

Роль уйнау — 1) йогынты, тәэсир ясау. *Габдулланың үсеше өчен гаять зур роль уйнаган һәм уйнаячак халык әдәбияты, аның җыры һәм бәете кинәт киләксез әйбер булып калды.* Ә. Фәйзи; 2) әһәмияткә ия булу. *Татар опера студиясе яшь композиторларны үз тирәсенә туплауда, аларның белемнәрен күтәрүдә, --- татар совет музыкасы үсешендә зур роль уйнады.* М. Җәлил; 3) сәбәпче, этәргеч көч булу. [*Каюмда*] *вакыт-вакыт нәрсәдер җитми яисә нәрсәдер артыбрак китә шикелле. Теш-тырнак белән коммунага ябышуында да шушы нәрсә роль уйнамыймы икән?* Ш. Камал; 4) берәр нәрсә функциясен үтәү, бурычын, вазифасын, хезмәтен үтәү. *Җир асты тимер юлы эшендә Париж эшчеләре бөтен дөнья күләмендә пионерлык ролен уйныйлар.* Г. Гали. **Рольгә керү** — 1) үзең башкарачак рольне, образны аңлау һәм үзеңне шул герой дип хис итә белү. [*Сәхнәдә*] *өнгә кила алмыйча азап чиккән егетне мең бәла белән уятып, ниһаять, үз роленә кертеп җибәрделәр.* А. Расих; 2) үз вазифаларын үзләштерү, үз хәленә төшенү. [*Сугышчы, сугышчан рольгә кереп:*] *Олуг башчым мине кичерсен! Ф. Бурнаш.*

РОЛЬГАНГ *и.* Йөкләрнең үз авырлыгы тәэсире белән хәрәкәт итә торган конвейер.

РОМ *и.* Шикәр камышының артык нык ачыган согыннан яки патокасыннан ясалган исерткеч эчемлек. *Уртадагы өстәлдә ашамлыклар, ромнан бушаган ике шешә.* Ә. Айдар.

РОМАН I *и. әд.* **1.** Гадәттә проза белән языла торгат катлаулы сюжетлы зур әдәби әсәр. *Тарихи роман. Фәнни-фантастик роман.* □*Бик мактalган китап дип, Алмаев „Москвадан ераkta“ романын китапханәдән алып кайтты.* И. Гази.

2. *сөйл.* Ир белән хатын һәм егет белән кыз арасындагы мәхәббәт, сөешү. *Әгәр роман дөньяга фаш ителсә, һаҗәр өчен үлем хурлыгы булачак, якты көнгә чыгарлык хәле калмаячак.* Г. Ибраһимов. *Үзеңә күпмедер буйсынган кыз белән роман башлау килешмәс, ярамас дигән уй мине тотыбрак торды.* Ә. Еники.

РОМАН II: **роман халыклары** — француз, румын, испан халыкларының гомуми атамасы. *Роман төркемена керә торган халыклар --- Көньяк-көнбатыш Европада яшиләр.* Дөнья кис. геогр. || *с. мәгъ.* Борынгы Рим культурасы нигезендә туган, шул культурага тыгыз бәйләнешле булган. *Роман стиле.* □*Төрмәгә охшаулы авыр, салмак, караңгы роман чиркәүләре готика чиркәүләренә алмаша барганнар.* Г. Гали.

РОМАНИСТ *и.* **1.** Роман телләре һәм әдәбияты белгече.

2. *махс.* Рим хокукы белгече.

РОМАНИСТИКА *и.* Роман халыклары культурасын, телен һәм әдәбиятын өйрәнә торган фән; роман филологиясе.

РОМАНС *и.* **1.** Җырлау өчен язылган кечкенә генә лирик характердагы музыкаль әсәр. *М. Мозаффаров халык җырларын эшләү, романслар һәм массовый җырлар язу буенча активлыгын үстерде.* М. Җәлил. *Лиза үзенең кечкенә, ләкин мәхәббәтле сопраносы белән бер романсның башын җырлап җибәрде.* Ф. Әмирхан.

2. Күләме зур булмаган, гадәттә музыкага салына торган лирик шигырь.

РОМАНТИЗМ *и.* **1.** XIX йөзнең башында әдәбиятта һәм сәнгатьтә классицизмга каршы буларак барлыкка килгән, реаль чынбарлыкны язучыларның таләпләре һәм тойгыларыннан, максатларыннан чыгып сурәтләргә, кеше образларын да тормыштагыча түгел, бәлки язучылар уйлаганча күрсәтергә омтылган әдәби юнәлеш. *Үзенең шактый чикләнгән булуына карамастан, романтизм әдәбият үсешендә яңа һәм әһәмиятле күтәрелеш булды.* Әдәбият белеме сүзлеге.

2. Әдәбият һәм сәнгатьтә кешенең бөеклеген ачык образларда күрсәтергә омтылучанлык һәм оптимизм белән сугарылган художество методы. *Романтизм алымы шартлылыктан киң файдалану мөмкинлеген бирә.* А. Әхмәдуллин.— *Минем әсәремдә, Айзирә туташ әйтмешли, аз-маз гына романтизм элементлары чагылып киткәли, бу тикмәгә генә түгел.* М. Хәсәнов.

3. Романтиклык, чынбарлыкны идеаллаштыру, хыялга (тойгыга, хискә) бирелү хәле.

РОМАНТИК I *и.* **1.** Романтизм тарафдары.

2. Романтикага, хыялга бирелүчән кеше. [*Җәүдәт Хәйдәргә:*] *Күрәм, син, туган, сугыш тимерлегендә чүкелгәннән соң да һаман да шул „төзәлмәс“ романтик булып калгансың.* Г. Бәширов. *Яшьләр алар— барысы да романтик.* И. Гази.

РОМАНТИК II *с.* **1.** Романтизм (1, 2 мәгъ.) рухындагы. *Романтик поэзия.* □ *Соңгы әсәр дә [„Безнең көннәр“] романтик йогынтысыннан азат түгел.* Г. Нигъмәти.

2. Романтикага (2 мәгъ.) бәйләнешле. *Илдар серне мәңге саклау турында әйтеп, дәфтәр битенә ант язды һәм кул куйды:— Инде син куй, нәнәм.— Барыннан да бигрәк сабыйны моның романтик ягы мавыктырды.* Г. Гобәй. *Ага белән сеңел арасында булган бу романтик очрашу каршында без, Гаяз белән, күзгә-күз карашып, ни әйтергә белми калдык.* М. Әмир.

3. Хыялланучан, романтикага (хыялга) бирелүчән, хис-тойгыга бирелүчән, нечкә күңелле. *Романтик хисле. Романтик табигатьле.*

РОМАНТИКА *и.* **1.** *к.* романтизм. *Горький әдәби хезмәтенең беренче дәверендә — шәхси азатлыкка, көрәшкә чакыручы, романтика моңнары катнаштырып язучы бунтарь.* Г. Нигъмәти.

2. Берәр нәрсәгә карата эмоциональлек, күңел күтәренкелеге тудыра торган, кешене алга әйдәүче хисләр, фикерләр һ. б. *Җыр булып калыр елларга яшьлек иртәсе, Яшьлекнең канат җилпегән романтикасы.* Ф. Кәрим. *Тойгылар үткенләшә, күңел үзеннән-үзе романтикага бирелә.* М. Әмир. *Ләкин Рабига [Нуруллиның] күңелендә бик тирән эз калдырган граждannар сугышы романтикасы белән бергә яшәде, бергә шәүләләнде.* А. Шамов.

РОМАНТИКЛАШТЫРУ *ф.* Кемне яки нәрсәне дә булса романтик (II, 2 мәгъ.) идеаллаштырылган рәвештә күзаллау; романтик (II, 2 мәгъ.) буяулар белән сурәтләү, тасвирлау.

РОМАНТИКЛЫК *и.* Романтика (2 мәгъ.), романтизм (3 мәгъ.) белән сугарылганлык. *Әдипнең һәрбер әсәрендә диярлек табигать күренешен бирүдә романтиклык үзен сиздерә тора.* Г. Нигъмәти.

РОМАНЧЫ *и.* Роман язучы.

РОМА'ШКА *и. бот.* Оешма чәчәкләреләр семьялыгыннан уртасы сары, читләре ак төстәге чәчәк ата торган үлән үсемлек. *Ромашкалар бар да ак, Аерылмый бер-береннән.* М. Җәлил. *Кәрешкә, мәтрүшкә, кәккүк чәчәкләре, --- ромашкалар, зәңгәр кыңгыраулар белән чуарланган, әле чабылып өлгермәгән болынның хуш исле җиләс һавасына туйганчы иркәләндек.* М. Әмир.

РОМБ *и.* 1. Кырлары үзара тигез, почмаклары туры булмаган параллелограмм. *Ромб параллелограмм булганлыктан, ул параллелограммның барлык үзлекләренә ия була.* Геометрия.

2. Совет Армиясенең югары команда составын аеру өчен 1943 елда погоннар кергәнче кулланылган билге. *Бер ромблы командир.*

РО'МБИК *с.* Ромб формасындагы, ромб рәвешендәге, кыек дүртбулак рәвешендәге.

РОМЛЫ *с.* Ром салынган. *Ромлы пирожный.*

РО'НДО *и. муз.* Төп темасы берничә тапкыр кабатлана торган музыкаль әсәр.

РОНДО' I *и.* Кабатланучы ике рифма белән тоташкан сигез юллы шигырь формасы (унөч һәм унбиш юллы катлаулы формалары да булган). *Хәзерге вакытта рондо иске формага ияреп язу өчен генә кулланылырга мөмкин.* Н. Гыйззәтуллин.

РОНДО' II *и.* Махсус түгәрәкләндерелгән язма, шулай ук басма шрифт. || Шундый шрифт белән язу өчен яссы очлы каләм.

РОССИАН *и. к.* россияле. *Россианнар исемен ишетү белән, Мәдәни дә гәрчә үзегез,— Урта гасыр иезуиты йөзен Хәтерләтә дә башлый төсегез.* Х. Туфан.

РОССИ'ЯЛЕ *и.* Россиядә яшәүче кеше.

РО'СТБИФ *и. махс.* Сыер итеннән кыздырып пешерелгән ашамлык, куырма; сыер түшкәсенең шундый ашамлык хәзерләү өчен китә торган сырт өлеше.

РОСТОВЩИК *и.* Мохтаҗ кешеләргә процент белән бурычка акча биреп торып, зур табыш алучы. *Крестьяннарны --- ростовщиклар да эксплуатацияләүче иде.* СССР тарихы.

РОСТОВЩИКЛЫК *и.* Ростовщик шөгыле. *Әгәр ростовщиклык капиталы капитализмга кадәрге формацияләр шартларында килеп чыккан булса, ссуда капиталын капиталистик җитештерү ысулы тудырды.* Политэкономия.

РО'ТА *и. хәрби.* Батальон составындагы гаскәри берәмлек. *Рота командиры.* □ *Отделениесе нык булган взвод, взводы нык булган рота, ротасы нык булган батальон гына җиңүгә ирешә ала.* Г. Әпсәләмов.

РОТАПРИНТ *и. махс.* Хезмәт кәгазьләре, документлар, реферат, бюллетень һ. б. ш. кебекләрне аз тиражда бастыру машинасы.

РОТА'ТОР *и. тех.* Сызым, кулъязма һәм рәсемнәрне бастырып күбәйтү аппараты.

РОТАЦИЗМ *и. махс.* „Р“ авазын дөрес әйтмәү күренеше.

РОТАЦИОН: ротацион машина — газета һәм китапларны күплэп баса торган махсус машина.

РОТА'ЦИЯ *и.* 1. *махс.* Ротацион машина.

2. *а.-х.* Чәчү әйләнеше циклында авыл хуҗалыгы культураларының бер әйләнеп чыгуы. *Дүрт басулы чәчү әйләнешендә ротация дүрт елга, алты басулы чәчү әйләнешендә алты елга сузыла.* А. Фаткуллин.

РО'ТМИСТР *и. хәрби.* Элекке Россиядә атлы гаскәрдәге офицер дәрәҗәсе һәм шул дәрәҗәдәге кеше (пехотадагы һәм башка гаскәрдәге капитан дәрәҗәсенә туры килә). *Ротмистр үз янына околоточный жандарм, городовой, ике пүнәтәйне алды да, бу бүлмәгә кереп, яшел постау ябылган өстәлнең янына урындыкка утырды.* Г. Ибраһимов.

РО'ТНЫЙ *и. хәрби.* Рота командиры. *Захаренко фамилияле бер ротныйлары бар иде аларның.* Г. Минский. *Рота командиры белән күзгә-күз карашып рапорт биреп торган Мәрдән абзый яшен тизлеге белән сулга борылды һәм ротный янындагы кызына карап каушап калды.* Г. Гобәй.

РОТО'НДА *и. махс.* Гөмбәзле, гадәттә колонналар белән әйләндереп алынган түгәрәк бина.

РО'ТОР *и.* Турбина, электр двигателе, нефть бораулау машиналары һ. б. ш. ның әйләнә торган өлеше, вал. [*Стрельцов*] *буровойга эшче булып кергәндә әле турбобур юк иде, ротор белән бораулап азапланалар иде.* И. Гази. *Турбина хәрәкәткә килде, ротор минутына 3000 тизлек белән әйләнә башлады.* С. Рафиков.

РО'ТОРЛЫ *с.* Роторы булган, ротор белән эшли торган. *Роторлы судно.*

РОЯЛИЗМ *и. тар.* Король хакимлеге яклы булу, король властена турылыклы булу.

РОЯЛИСТ *и. тар.* Роялизм тарафдары, король хакимлеген яклаучы кеше.

РОЯЛИ'СТИК *с. тар.* Роялизмга бәйләнешле, роялизм рухындагы. *Роялистик карашлар.*

РОЯЛЬ *и.* Металл кыллары горизонталь урнашкан, клавишлы музыка инструменты. *Наилә рояль янына утырып уйнарга теләп карый да торып китә.* Р. Ишморат. *Яшь кенә малай, рояльнең ике педаленә дә басып, колак тондырып уйный.* Ш. Усманов.

РСДРП *и. тар.* Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (*русчасы:* Российская социал-демократическая рабочая партия). *Казан большевикларына ярдәмгә, үзәкнең киңәше буенча, РСДРПның Төньяк Комитетыннан вәкил җибәрелде.* А. Расих.

РСФСР *и.* Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы (*русчасы:* Российская Советская Федеративная Социалистическая Республика), территориясе, халык саны һәм хуҗалыктагы әһәмияте ягыннан 15 союздаш республика арасында иң зурысы.

РТС *и. тар.* Техник ремонт станциясе (*русчасы:* ремонтно-техническая станция). *РТСтан монтажчы слесарьлар җибәрергә директорның вәгъдәсен ишеткәч, колхоз кешеләре канатланып киттеләр.* С. Рафиков.

РУБИ'ДИЙ *и. хим.* Көмешсыман ак төстәге йомшак металл, химик элемент.

РУБИ'ЛЬНИК *и. тех.* Электр тогын тоташтыра яки өзә торган җайланма. *Стена буйларын казып, кабельләр үткәрәләр һәм станок моторларына ток кертәләр, рубильниклар асалар.* А. Расих.

РУБИН *и. махс.* Кызыл төстәге асылташ; кызыл якут. [*Кремльнең*] *Манара очларына Менеп баксаң югары, Мәскәү Кремленең дә Күренер рубиннары.* Н. Исәнбәт. | *с. мәгъ. Күккә күтәрелгән төсле янып тора Рубин йолдызларның утлары.* Ә. Ерикәй. || *күч. с. мәгъ.* Шул төстәге, кызыл. *Тын тирбәлеп яткан зәңгәрлеккә Алтын-янгын нурлар түгелә, Шул нурларның рубин шәүләләре Күтәрелә Совет күгенә.* Ш. Маннур.

РУ'БКА *и.* 1. Корабльнең өске палубасында идарә итү постлары урнашкан корылма. *Капитан юл күрсәтүчене рубкага алып менде.* С. Сабиров.

2. Нинди дә булса махсус бер эш өчен билгеләнгән бүлмә. *Радио рубкасы.*

РУ'БРИКА *и.* Газета, журналларда бер үк темага караган мәкаләләрнең гомуми башы, исеме. *Журналда „Язучының күңел дәфтәреннән“ рубрикасы астын-*

да хикәягә тартым --- парчалар басылгалауны мин уңай бер күренеш дип табам. Ф. Хөсни.

РУДА *и.* Составында металл(лар) яисә аның (аларның) кушылмалары булган тау токымы, табигый минерал, чимал; мәгъдән. *Эшчеләр капчыкларга салып баржадан кырыйга күкерт рудасы ташыйлар.* Ш. Камал. *Кызыл ком күк руда агылып тора, Вагонеткаларга төялеп.* Ш. Маннур.

РУДАЛЫ *с.* **1.** Руда чыга торган. *Рудалы урыннар.*

2. Составында руда булган. *Рудалы токым.*

РУДИМЕНТ *и. биол.* Организмның эволюцион үсеше процессында үзенең әһәмиятен югалткан, үсми калган, калдык әгъза (мәсәлән, кешенең сукыр әчәк үсентесе, койрык сөяге һ. б. ш.).

РУДИМЕНТАР *с.* Рудимент булган, җитлекмәгән хәлдәге; калдык. *Рудиментар мускуллар.*

Рудиментар органнар — организмның тарихи үсеше процессында үзенең беренчел әһәмиятен югалткан һәм үсми калган орган. *Рудиментар органнар кешенең хайваннардан килеп чыгуын исбат итүче иң мөһим дәлил булып тораллар.* Биология.

РУДНИК *и.* Файдалы казылмалар чыгару өчен җир асты корылмалары системасы; шул эшләрне оештыра һәм башкара торган тау промышленносте предприятиесе. *Рудник янынан Госман карт эш киемендә иңбашына тимер көрәк күтәргән хәлдә килеп чыга.* Ш. Камал. [*Гарәфи*] *белән бергә киткән Сугышлы егетләренең күбесе я шахтада, я рудникта, я заводта урнашып калганнар.* Г. Әпсәләмов.

РУЗА *и. дини диал. к.* ураза. — *Дүвәл заманда сезнең шикелле үк эш кешеләре шушыннан да озынрак көннәрдә руза тотканнар.* Ф. Әмирхан. *Муса Бигиев соңгы китабында озын көннәрдә руза тотуны мөселманнарга фарыз санамый.* И. Нуруллин.

РУЛЕВОЙ *и. махс.* Суднода, көймәдә руль белән идарә итүче. [*Шәрәфи агай:*] *Әнә карагыз, нишләтә көймәне! Рулевой авызын ачмаса, шулай да котылырлар...* Ш. Камал. *Рулевой мачта очыннан флагны төшерде, сигнал утларын кабызды.* С. Сабиров.

РУЛЕТ *и. махс.* **1.** Сөяге алынып, тозлап эшкәртелгән дуңгыз боты ите — салкын азык итеп кулланыла торган ашамлык.

2. Тапаган иттән яки төйгән бәрәңгедән эченә нәрсә дә булса салып, озынча түгәрәк формада пешерелгән ашамлык.

3. Эченә варенье, ит һ. б. нәрсәләр салып пешерелгән озынча түгәрәк катлама.

РУЛЕ'ТКА *и.* Сантиметр һәм метрларга бүленгән тар корыч, киндер яки клеенка тасма футляр эчендәге валикка урала торган итеп эшләнгән үлчәү приборы (зур булмаган араны үлчәү өчен кулланыла).

РУЛОН *и. махс.* Түгәрәк төргәк (мәсәлән, кәгазь, обой, материя һ. б. төргәкләре). *Кәгазь рулоны. Тукыма рулоны.* □ *Ишек алдында машиналардан зур-зур рулоннарны тәгәрәтеп газета кәгазе бушаталар.* А. Гыйләҗев.

РУЛЬ *и.* Кораблъ, самолет, автомобиль һ. б. ш. транспорт чаралары белән идарә итү җайланмасы. *Майор руль янына үзе менеп утырды һәм машинаны урам буйлап алып китте.* А. Шамов. *Руле һәм педале сынган велосипед күтәреп, тирләп-пешеп, Хәйрүш ашыгып керә.* М. Җәлил.

РУМЫН *и.* Румыниядә яшәүче төп халык һәм шуның бер кешесе. *Җыелган халык арасында --- әллә никадәр чех, румын, хорват, үзбәк һәм башка халыклар бар иде.* Ш. Усманов.

РУМЫ'НИЯЛЕ *и.* Румыниядә туып үскән яки шунда яшәүче кеше.

РУМЫ'НЧА *рәв.* Румын телендә; румыннарга охшаш.

РУН *и.* Таш, корал, йорт кирәк-яраклары кебек нәрсәләрдә сакланып калган, кайбер борынгы кабиләләрдә кулланылган иң борынгы язмалар. *Арами алфавитыннан борынгы фарсы, борынгы еврей, гарәп, уйгур, грузин язулары, төрки руннары һ. б. үсеп чыга.* Х. Курбатов. || *с. мәгъ.* Шуңа бәйләнешле. *Рун язмалары.*

РУ'НИК *с.* Рунга караган, рунга бәйләнешле. *Имзаларның берсе адәм танырлык, калганнары борынгы руник язмаларны хәтерләттеләр.* А. Гыйләҗев.

РУ'ПОР *и.* **1.** Конус формасындагы тавыш көчәйткеч труба. *Рупор тавыш дулкыннарына һәр якка чәчелергә ирек бирмичә, аларны бер юнәлештә генә китәргә мәҗбүр итә.* Физика. *Скважина янындагы кыргыч будкасының яссы түбәсендә --- кечкенә рупор каралып күренә.* Нефть тур. хик.

2. *күч. кит.* Кемнең дә булса фикерләрен, карашларын таратучы, үткәрүче. *Кайберәүләр шундый хәбәрләрне Ташый торгач түкми сүзен дә, әверелгәнен дошман рупорына Сизми кала хәтта үзе дә.* Ә. Исхак.

РУС *и.* Элек Россия империясенең, ә хәзерге көндә РСФСР һәм СССРның күпчелек халкын тәшкил итә торган көнчыгыш славян халкының атамасы һәм шул халыкның бер кешесе. *Мин Татарстанда руслар белән татарларның ничек кулга-кул тотынышып эшләүләрен сөйлим.* Г. Гали. *Өстәлнең икенче башында --- кырык яшьләрдә бер рус икенче журналны карап утыра иде.* Ф. Әмирхан. || *с. мәгъ.* Шул халыкка караган, шул халык барлыкка китергән. *Рус теле. Рус культурасы.* □ *Мансур --- рус әдәбияты белән рус сәнгатендә тәрбияләнгән кеше иде.* Г. Әпсәләмов.— *Рус театры мине бик кызыктыра башлады.* М. Гали.

Рус миче — азык, ипи һ. б. ш. пешерү, өйне җылыту өчен махсус корылмалы итеп эшләнгән киң авызлы мич.

РУСИЗМ *и.* Рус теленнән алынган сүз яки тәгъбир.

РУСИСТ *и.* Русистика буенча белгеч.

РУСИ'СТИКА *и.* Рус телен, культурасын өйрәнә торган фәннәр җыелмасы; рус филологиясе.

РУСЛАШТЫРУ *ф. полит.* Патша Россиясендә рус булмаган халыкларны көчләп руска әйләндерергә тырышу, тел һәм гореф-гадәт буенча көчләп рус ясау, рус итү. *Патша хөкүмәте милли культураның һәртөрле күренешен буарга омтылды, рус булмаган милләтләрне көчләп руслаштыру политикасы үткәрде.* М. Җәлил.

РУСЛАШТЫРУЧЫ *и. полит.* Руслаштыру политикасын үткәрүче, руслаштыру тарафдары (патша Россиясендә).

РУСЛАШУ *ф.* Тел һәм гореф-гадәт буенча руска әйләнү, рус булып китү.

РУ'СЧА *рәв.* **1.** Рус телендә. *Дәфтәргә русча гына түгел, латин хәрефләре белән дә бик күп чит сүзләр язылган иде.* А. Шамов. [*Малайлар*] *өчен Казан малаеның шундый оста итеп русча сөйләшә белүе чиктән тыш вакыйга иде.* Г. Гобәй.

2. Руслар киенгәнчә, русларда булганча. [*Кызларның*] *бөрсе 17—18 яшьләрдә, саргылт кына, уртача буйлы, өстенә русча киенгән, ләкин башына кечкенә генә калфак әләктереп, өстеннән ак шарфик салган.* Ф. Әмирхан.

РУ'СЧАЛАП, РУ'СЧАЛАТЫП *рәв. сөйл.* Русча, рус телендә. *Янгура --- шоферга русчалап больница номерын әйтте.* Г. Әпсәләмов. [*Килмәүчеләр*] *турында хәлфә русчалатып нидер сорашты һәм тагын кенәгәгә нидер билгеләп куйды.* Ә. Фәйзи.

РУ'СЧАЛАШТЫРУ *ф. сөйл.* Рус теленә тәрҗемә итү.

РУ'ТА *и. бот.* Рутачалар семьялыгыннан көньякта үсә һәм яфрагыннан эфир мае алына торган, сары чәчәкле, агулы куак-үсемлек.

РУ'ТАЧАЛАР *и. бот.* Әфлисун, лимон, мандарин һ. б. ш. керә торган ике орлык өлешле үсемлекләр семьялыгының атамасы.

РУТЕ'НИЙ *и. хим.* Платина группасына керә торган сорырак көмешсыман төстәге җиңел металл (электр лампочкаларының кылын эшләүгә китә).

РУТИНЁР *и. кит.* Искелекне яклаучы, иске шаблон буенча эш итүче, иске гореф-гадәтләргә ябышып ятучы.

РУТИНЁРЛЫК *и.* Искелек, торгынлык, катып калганлык.

РУХ *и.* **1.** Аң, фикерләү, психик сәләт. *Таза рухлар була тик таза тәндә, Куркак була һәрбер начар рухлы бәндә.* Г. Камал. *Ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның --- рухлары яхшыны вә начарны аермый.* Г. Тукай. || Дөньяга караш, мәсләк. *Минем тәнемне бөгә алырсың, ләкин рухымны бөгә алмассың.* Ф. Әмирхан. || Материалистик философиядә һәм психологиядә: югары төзелешле материянең аерым бер махсус үзенчәлеге буларак фикерләү, ан. || Идеалистик философиядә: барлык әйберләрнең, күренешләрнең нигезендәге материаль булмаган беренчел башлангыч. *Идеализмның --- төп карашы бер нәрсәгә кайтып кала: имеш, дөньяның, безнең чолганышыбызның асылы — идея, рух, аң.* М. Абдрахманов. || Дини ышанулар буенча: кешедә материаль булмаган, үлемсез илаһи башлангыч; җан. *Шикле хәбәр Хәмидәне кайгыртса да, ул Гарифның рухына хәерсәдакалар бирергә теләсә дә, мулла белән Фәхреислам агай ашыкмый торырга, сабыр итәргә куштылар.* М. Гафури.

2. Психик халәт, кешенең, коллективның мораль көче. *Кешене дәртләндерә һәм аның рухын сафландыра торган хезмәт дәрте аларны бөтенләй үзгәрткән, бөтенесен җилкендергән иде.* Г. Бәширов. *Чиләбе отрядының рухы шәп иде.* Ш. Усманов. || Дәрт, омтылыш, илһам. *Түрә кызы, бертөрле рух вә илһам белән рухланып, хәзерге Ашказар көен җырлап җибәрә.* Г. Тукай.

3. Кешенең эчке, психик дөньясы, күнеле, аңы. [*Мавия:*] *Рухыма каршы булган бер тормышка керү мине һич бәхетле итмәс.* М. Фәйзи. *Кызыксындырган сорауларга җавап алынып беткән, ни дә булса бүтән темага сүз кузгатыр идем, Вәсилә ханымның рухына туры килмәгән нәрсә килер --- дип шикләнәм.* Ф. Хөсни.

4. Дингә, мифологиягә, мистикага ышанучылар өчен табигатьтән өстен, җисемсез зат. *Мин сихерләр, җеннәр, рухлар арасында чорналып калдым.* М. Фәйзи. *Бу сихерле, моңлы өннәр Нинди җирдән ишетелә; Нинди рухлар җырлый, бу Көйләр миңа кайдан килә?* Һ. Такташ.

5. Берәр нәрсәнең төп эчтәлеге, асылы, характерлы үзенчәлеге, юнәлеше. [*Париж*] *музеенда рыцарьлар рухы аңкый.* Г. Гали. [*Газетада*] *революцион рухта язылган мәкаләләрне дә бик еш очратырга туры килә.* М. Гали. || Кемнең дә булса үз-үзен тотышын, фикерләү юнәлешен билгели торган нигез, башлангыч.— *Әтием полковник, абзам офицер булганлыктанмы, әллә үземдә дә гаскәри рух булганга, сезнең эскадронны бик яраттым.* К. Тинчурин.

Рух кертү (өрү, бирү) — рухландыру, дәртләндерү. [*Әдәбият кичәсе*] *милләт балаларының үлгән күңеленә рух өрәчәктер.* Г. Тукай. *Шулай бирә миңа яшәү рухын Синең хатың авыр көннәрдә.* Ә. Ерикәй.

Рух күтәрелү — күңел күтәрелү, дәртләнү, рухлану. *Партизан көрәшләрендә даны чыккан Урал көрәшчеләре булып, аларның исемнәрен ишетү белән рух тагын да күтәрелде.* Ш. Усманов.

Рух күтәрү — дәртләндерү, рухландыру. [*Фрунзеның сугышчыларга*] *дәрт өстәү, аларның рухларын күтәрү өчен күңеленең иң тирән урыныннан чыккан иң кадерле сүзләрен әйтәсе килә иде.* Г. Бәширов.

Рух төшү (сүнү, суыну) — күңеле төшү, төшенкелеккә бирелү. *Бетсә дә көч-дәрманым, Рух, дәртләр әле сүнмәгән.* Б. Рәхмәт. *Һич тә күңелем ачылмаслык эчем пошса, Үзүземне күрәлмыйча, рухым төшсә, --- Шул вакытта мин кулыма китап алам.* Г. Тукай.

РУХАН *рәв. иск.* Рухи яктан. [*Лалә:*] *Мин Шәрәф белән рухан берләшкәнмен. Никахлар гына мине аннан аера алмый.* М. Фәйзи.

РУХАНИ *и.* **1.** Дин башлыгы. [*Такташ*] *феодал руханиларның һәм диннең, иске мәдрәсә схоластикасы һәм дини уйдырмаларның халык массасы аңын агулавын күрә, ачыграк төшенә килде.* Г. Нигъмәти.

2. *к.* рухи. *Бай табигатьле кыз ул, ләкин бөтен рухани байлыгын ваклап әрәм итә, чәчелә, сибелә: кавалерист та ул, парашютчы да ул.* И. Гази.— *Унбиш-егерме ел шушы чүплек базында [мәдрәсәдә] черегәннән соң, дөньядагы барлык хорафатларны башыбызга җыябыз да тормыш көтәргә сәләхиятсез, дөньяга яраксыз, рухани гарип кешеләр булып чыгабыз.* Т. Гыйззәт.

РУХАНИЛЫК *и.* Рухани (1 мәгъ.) вазифасы. *Муса Җәлил һәм аның иптәшләре кайда һәм кайчан үтерелүе дә ачыкланды инде. Моны Шпандау төрмәсендәге католик тоткыннар арасында руханилык эше алып барган патер Г. Юрытко раслый.* М. Гайнуллин.

РУХИ *с.* **1.** Рух (1 мәгъ.) белән бәйләнешле; *кирәсе:* матди. *Бу кеше дә Шакирда әнә шундый рухи бер җиңеләю тудырды.* Г. Минский.

2. Кешенең эчке дөньясы, рухы белән бәйләнешле. *Рухи якынлык. Рухи байлык.* □ *Берничә минут вакыт без икебез дә тынып калдык, бу тынлык һәр икебезнең дә рухи халәтенә бик яхшы туры килә.* Ф. Хөсни. *Ир дә, хатын да үзенең шәхси иркенә, үзенең рухи дөньясына хуҗа булып калырга тиеш!* Р. Ишморат.

Рухи азык — җан азыгы, аң-белем, психиканы тәрбияли торган күренеш. [*Мортазин*] *миллионнар белән идарә итүдән тәм һәм рухи азык таба, үзен көчле итеп сизә.* Г. Әпсәләмов.

РУХЛАНДЫРУ *ф.* Илһам, дәрт бирү, илһамландыру, дәртләндерү, көч кузгату, уяту. [*Паровоз кычкырган тавышлар*] *гүяки: „Әйдә, әйдә, зарар юк, алып барсыннар, актыкта барыбер җиңәрбез!— дип, Мохтарның күңеленә көч бирә, аны тагын да рухландыра иделәр.* Ш. Камал. [*Газиз:*] *Синең мәхәббәтең, Рәхимәкәй, мине җиңүгә рухландырды, үлемнән алып калды.* А. Әхмәт.

РУХЛАНУ *ф.* **1.** Дәртләнү, җанлану, күңел күтәрелү. *Ялкын кебек кабынам әштә, Мин дәртләнәм, рухланам.* Ә. Ерикәй. [*Авылларга*] *чыгып йөрүләрдән Мостафин көч җыеп, рухланып кайта торган иде.* Ә. Еники.

2. Җанлану, рух, җан керү, хәрәкәткә килү. *Парторгның ябык йөзе эчке нурдан рухланган, яктырган, ә күкрәктән чыккан тавышында тирән ышаныч, ниндидер тантана яңгырый иде.* Г. Әпсәләмов.

РУХЛЫ *с.* Җанлы, дәртле, шат күңелле. *Авыл — изге ул, табигый ул, саф авыл. Кешеләре дәртле, рухлы аның.* М. Фәйзи. *Ашкынамын мин [мәңге] бетмәс урынга, мәңгегә, Мәңгелеккә — мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!* Г. Тукай.

РУХСЫЗ *с.* 1. *күч.* Тормыш әсәре булмаган, җансыз. *Хәсән [кышкы] иртәләрне яратмый, аларны тормышның рухсыз ягы дип белә иде.* Ф. Әмирхан. || Дәртсез, кәефсез, күңелсез, төшенке күңелле. *Элекке дәртле, канатлы Җиһангир күренми иде, арганмы, сүнгәнме, ничектер рухсыз.* Г. Ибраһимов.

2. *рәв. мәгъ.* Дәртсез, күңелсез, салкын. *Күңел төшенкелеге аркасында, без һәммәбез дә, бер зур нәрсәбезне югалткан кебек, рухсыз эшли идек.* М. Гафури.

РУХСЫЗЛАНУ *ф.* Рухи яктан үзгәрү, күңелсезләнү, төшенкеләнү.— *Җәмәгать,— диде Сафин,— шыпыртлап сөйләшүләрне куеп торыйк, мәҗлес рухсызланып китте.* Ш. Камал. *Гражданнар сугышының беренче айларында каһарманча сугышкан, армыйталмый эшләгән егет соңгы вакытларда нәрсәгәдер рухсызланып киткән иде.* Ш. Усманов.

РУХСЫЗЛЫК *и.* Рухсыз булу хәле. [*Камил әфәнде*] *„Кара урман“ны җырлады һәм --- аны бозмады. Тыштагы самимиятсезлек вә рухсызлык та --- хис ителмәде.* Ф. Әмирхан.

РУ'ЧКА *и. сөйл.* Агач, калай, пластмасса һ. б. ш. нәрсәләрдән бер башына каләм куела торган итеп эшләнгән язу коралы, каләм сабы. *Миләүшә, укып бетереп, ручка тоткан кулы белән иягенә таянды да уйга калды.* И. Гази.

РЫ'ЦАРЬ *и.* 1. *тар.* Көнбатыш Европада феодализм дәверендә атлы гаскәрдә хезмәт иткән феодал.

2. *күч. кит.* Кемне яки нәрсәне дә булса фидакарь рәвештә яклаучы, аның намусын саклаучы, аның өчен үзен аямаучы кеше.

РЫ'ЦАРЬЛАРЧА *рәв.* Үзен үзе аямыйча, рыцарьлар (2 мәгъ.) кебек.

РЫ'ЦАРЬЛЫК *и.* 1. *тар.* Рыцарь хезмәте, вазифасы.

2. *күч.* Фидакарьлек, үз-үзен аямаучылык.

РЫЧАГ *и.* Таяну ноктасы тирәсендә борыла ала һәм аз көч куеп авыр нәрсәне күтәрү өчен хезмәт итә торган җайланма. *Стрельцов --- ишек алдындагы су колонкасы янына йөгереп чыкты. Малайлар рычагка басып тордылар.* И. Гази. *Астан туннель казып, көчле рычаглар белән әкрен генә икенче урынга шудыралар йортларны.* С. Рафиков. || Нәрсәнең дә булса юнәлешен үзгәртү яки берәр нәрсә белән идарә итү өчен хезмәт итә торган тотка. *Тизлек рычагы.* □ *Сары утны күргәч, машинист контроль рычагны тарта.* Ж. Тәрҗеманов.

РЫЧАГЛЫ *с.* Рычагка көйләнгән, рычагы булган. *Рычаглы тормоз. Рычаглы конструкция.*

РЮКЗАК *и.* Аркага асу өчен махсус тасмалары яки каешлары булган юл капчыгы. *Кызу атлап Иванов килеп керә, кулында рюкзак, аның эчендә ташлар.* А. Әхмәт. *Мич кырыенда, идәндә, тыгыз итеп тутырылган спортчылар рюкзагы.* Г. Әпсәләмов.

РЮ'МКА *и.* Эчемлекләрне салып эчәр өчен гадәттә пыяладан ясалган кечкенә савыт. *Мин сары эчемлек белән тулы рюмканы авызыма китердем.* М. Әмир. *Рюмка нечкә билле түгел, кечкенә генә стакан формасында иде.* Ш. Камал.

РЯДОВОЙ *с.* Командирлар составында булмаган, гади. *Ул бик озак уйланып торды, аннары рядовой составның исемлеген сорады.* Г. Әпсәләмов. || *и. мәгъ.* Солдат. *Рядовой --- урынныннан торды.* А. Шамов. *Рядовойлар төнен йоклаганда, Мин йокламыйм шатлык, кайгыдан.* Ф. Кәрим.

РЯ'ПУШКА *и. зоол.* Балтик һәм Төньяк диңгезләре бассейнында яши торган вак балык төре.

РЯ'СА *и. дини.* Христиан руханиларының билләп тегелгән киң җиңле озын өске киеме.

РӘВЕШ I *и.* 1. Тышкы күренеш, кыяфәт; форма. *Гаилә тормышының рәвеше саклансын өчен генә торучылар да аз түгелдер.* С. Рафиков. [*Шәрәфнең*] *машинага утырып йөргәндәге рәвешен карап тору бик күңелле.* М. Фәйзи.

2. Нинди дә булса эшнең башкарылу формасы, характеры. *Габдулла аның җырыннан түгел, аның җырлау рәвешеннән бик зур ләззәт таба.* Ә. Фәйзи. *„Тирән тамырлар“ озын хикәя рәвешендә язылган.* Г. Нигъмәти.

3. „Рәвештә“ формасында кайбер сыйфатлар белән килеп, тезмә рәвеш ясый. *Аңлы рәвештә. Оешкан рәвештә.* □ *Тирә-юньне яктыртып, һавага өзлексез рәвештә ракеталар күтәрелә.* А. Шамов. *Ватан сугышы башлангач, [ул] педагогия институтының өченче курсыннан ирекле рәвештә армиягә киткән.* Ә. Еники.

4. *бәйл. функ.* **рәвешендә, рәвештә.** Кебек, шикелле, сыман. *Көймә бераздан бер батып, бер калкып уйнаган кармак калкавычы рәвешендә генә күренә башлады.* Ш. Камал.

РӘВЕШ II *и. лингв.* Эш-хәлнең билгесен яки билгенең билгесен белдерә, морфологик яктан төрләнми торган сүз төркеме.

РӘВЕШЛЕ *бәйл. к.* рәвеш (4 мәгъ.). *Соры томан рәвешле болытлар җирне баскан төсле тоташып җиргә салынганнар.* Ш. Камал.

РӘВЕШЛӘШҮ *ф.* Рәвеш II ролендә килү, рәвешкә әйләнү. *Сыйфатларның рәвешләшүе.*

РӘВЕШСЕЗ *с.* Килешсез, ямьсез. [*Аның*] *рәвешсез борыны кутырлардан арынып тормый иде.* К. Тинчурин.

РӘВЕ'ШЧӘ *рәв.* 1. „Шул“, „бу“, „ошбу“ күрсәтү алмашлыклары белән килеп, тезмә рәвеш ясый. *Шул рәвешчә бераз баруга, зениткалар тынды.* Г. Гобәй.

2. *бәйл. функ.* Шикелле, кебек. [*Бизгәк*] *бераздан Казандагы рәвешчә бөтен тамырларны дерелдәтә башлады.* Г. Тукай.

РӘД: рәд итү (кылу) *иск.*— кабул итмәү, кире кайтару, кире кагу. *Мин үзем өйләнү турысында ашыгу тарафында булмасам да, әнкәйнең теләгенә туташның хасияте дә кушылгач, рәд итәргә көчем юклыгын башта ук сиздем.* Ш. Камал. [*Кыз*] *рәд кылганда, айлар йөреп, Үзеңне яратырга өндәдең.* М. Гафури. **Рәд җавабы** *иск.*— кире җавап, үтенечне кире кагу. *Угылыннан аерылырга теләмәгәнгә, Зөләйха абыстай әүвәлге малайга рәд җавабы бирде.* Г. Ибраһимов.

РӘ'ДДЕ *кис. иск.* Инкярлау кисәкчәсе: түгел.

Рәдде бичара — бичара түгел, бичара булмаган. *Рәдде бичара кыз.*

РӘЕШ: рәешкә кия торган — яхшыга, чистага, мәсәлән, кунакка, театрга һ. б. җиргә барганда, кеше арасына чыкканда кия торган. [*Кыз*], *кием шкафын ачып, рәешкә генә кия торган күлмәген кулына алды.* Сов. әд.

РӘИС *и.* 1. Кайбер учреждение, оешма, җәмгыять яки аларның бүлекләренең җитәкчесе; председатель. [*Мирзахан:*] *Мирвәли абый, иртәгә мин Биктимер абзыйны авылга рәис итеп сайлауны үткәрергә уйлыйм.* Т. Гыйззәт. *Начальник урынбасары кич белән колхоз рәисен күрде һәм иртәнге тау белән картларга җылы иртәнге аш хәзерләргә кушты.* М. Җәлил.

2. Җыелышны, утырышны алып баручы, председатель. *Берәү, рәистән сүз дә сорап тормыйча, --- сөйләргә тотынды.* Ш. Усманов. *Хөкем әгъзалары да, гаепләнүче белән яклаучы да, рәис үзе дә, төрле яктан килеп, дхмәт Уразовны тарткалап карадылар.* Г. Ибраһимов.

РӘИСЛЕК *и.* Рәис вазифасы, рәис булу. *Беренче ноябрьда көндез өченче Дума ачылып, 371 тавыш белән рәислеккә октябрист — Николай Алексеевич Хомяков сайланды.* Ф. Әмирхан.

Рәислек итү — рәис вазифасын башкару, рәис булу.

РӘЙХАН *и. бот.* Зәңгәр чәчәкле хуш исле гөл; *русчасы:* базилик. *Бакчаларга кердем, рәйхан күрдем.* Ә. Ерикәй.

РӘКАБӘТ *и. иск.* Ярыш, көндәшлек, башкалардан өстен булырга тырышу, конкуренция.

Рәкабәт итешү — көнләшү. *Кием-фәлән эҗһәтеннән (хатыннар) арасында бер-берсенә рәкабәт итешү булганга күрә, күзләре бер-берсенең киемендә улдыгы кебек, сүзләре дә шул кием-фәлән кебек әһәмиятсез мәсьәләләр турысында иде.* М. Гафури.

РӘКӘГАТЬ *и.* Намазның аягүрә тору, иелү һәм башны җиргә куюны әченә алган бер өлеше. *Фарызның икенче рәкәгатен укыганда, хажи әфәнденең хәтеренә төшвиш килеп, намазны бозды.* Ш. Мөхәммәдев. [*Садыйк хажи*] *өч рәкәгать ахшам фарызы урынына алтымы, җидеме рәкәгать укып ташлады.* Ш. Камал.

РӘНҖЕТҮ *ф.* Кемгә дә булса хаксызлык күрсәтү, кыерсыту, кысу, урынсызга кимсетү; җәберләү. *Миңкамал абыстай ул — киң күңелле кеше, бирәүне дә үпкәләтергә, рәнҗетергә теләми.* А. Шамов. *Килене рәнҗетүенә йөдәгән Миңзифа әби, актык сәләмәләрен җыеп, берничә кадак он, майга алмашып булмасмы дип, авылга китә.* Г. Нигъмәти.

РӘНҖЕШ *и.* **1.** Хаксызга, урынсызга кимсетү, кыерсыту, җәберләү. *Гайшә өстенә ата-анасыннан рәнҗешләр, ағаларыннан кыйнаулар башланды.* Г. Ибраһимов.

2. Үзенә карата булган хаксызлыктан, урынсызга кимсетелүдән, җәберләүләрдән, кыерсытылулардан туган ачыну, әрнү тойгысы. *Галләм абзыйның соңгы хатында Вахитнең сүзләренә каршы бераз рәнҗеш --- өстенә шушы яңа хәбәр бар иде.* М. Гафури.

Рәнҗеш күрсәтү — үпкәләү, хәтер калу. *Ул минем шаянлыкны белгәнгә, күмәчен алганга һич рәнҗеш күрсәтмәү өстенә, кайчакта миңа бирә торган өлешне арттырып бирә башлады.* М. Гафури. **Рәнҗеш төшү** — кемне дә булса рәнҗеткән, кимсеткән кешенең берәр төрле бәла-каза күрүе, авырлыкка дучар булуы турында әйтелә. *Терелдем. Нәфес — шайтан бит: әй, ул татарның рәнҗеше төшәме соң дип уйладым.* Г. Ибраһимов.

РӘНҖЕШЛЕ *с. к.* рәнҗүле. [*Вахит*] *үзенең китүенә болай көлеп караучыларга рәнҗешле бер караш белән көлеп карап, башын түбән иеп, төшкән фатирына туп-туры кайтып китте.* М. Гафури.

РӘНҖҮ *ф.* **1.** Хәтер калу, үпкәләү, нәрсәне дә булса авыр кабул итү.— *Харрас җаный, рәнҗемә миңа!— диде дә* [*Гөлнар*] *шәп-шәп атлап өенә таба китте.* Ә. Айдар. *Шәп-шәрә урынга тормыш корып җибәрүе бик авырга килсә дә, Тимери рәнҗемәде.* Г. Бәширов.

2. Ризасызлык белдерү, килешмәү, күңеле каршы булу.— *Анам рәнҗи, Калтайга бармасаң, телемне алмасаң, сиңа имезгән ак сөтемне бәхилләмәм, ди.* Г. Ибраһимов.

РӘНҖҮЛЕ *с.* Рәнҗү белдергән. *Арадан бер карт казакъ, торып, рәнҗүле, шелтәле тавыш белән карт кунакка сүз ачты.* Г. Ибраһимов. *Бары Шәһидә генә рәнҗүле караш белән Хисамга текәлде.* А. Расих.

РӘСЕМ *и.* **1.** Берәр предмет, зат һәм күренешнең карандаш, каләм, күмер, буяулар һ. б. белән ясалган сурәтләнеше, күчермәсе. *Искәндәр, чемоданын ачып, ак киндергә төрелгән берничә рәсем чыгарды.* Г. Гобәй. *Левитанның „Чоңгыл янында“ дигән рәсемен караганда, аркылы салган бүрәнәләргә басып аргы яктагы урманчылыкка чыгып китәсе килә башлый.* Г. Бәширов.

2. Кемнең дә булса сурәте: фотокарточка. *Зиннәт инде фотоаппаратны гына түгел, хәтта үзе төшергән рәсемнәрне дә ап-ачык күрә.* А. Шамов. *Соловьев Газинурның кулыннан Матросовның рәсемен алып карап тора башлады.* Г. Әпсәләмов.

Рәсем алдыру — рәсемгә төшү.

РӘСЕМЛЕ *с.* Рәсем төшерелгән, рәсем ясалган, рәсемнәр урнаштырылган. *Көннәрнең берендә, көндезге аштан соң, уртадагы өстәл тирәсендә яралылар кайсы шашка уйнап, кайсы рәсемле журналлар карап утыралар иде.* М. Гали. *Повар --- Хәлимгә бик матур, бик күп рәсемле русча китап алып кайтып бирде.* Г. Гобәй.

РӘСЕМЧЕ *и. к.* рәссам.

РӘСМИ *с.* **1.** Хөкүмәт, администрация, урындагы кеше тарафыннан билгеләнгән, расланган, алар тарафыннан чыгарылган. *Рәсми белдерү. Рәсми документ. Рәсми сводка.* □*Кымыз сезоны июнь башыннан рәсми төс алды.* Ш. Мөхәммәдев. [*Сеңелкәш хатта*] *әткәйнең үлүе турында рәсми язу килгәнлеген әйткән.* Г. Әпсәләмов. || Хөкүмәт тарафыннан куелган, билгеләнгән. *Беренче сорау мәдрәсәнең рәсми башлыгы, мәхәлләнең имамы Гали хәзрәттән булды.* Г. Ибраһимов. || Хөкүмәт документларына, эш кәгазьләренә хас. *Рәсми телдә. Рәсми терминология.*

2. Кабул ителгән форма буенча үткәрелә торган, барлык формаль яклары сакланган. *Рәсми утырыш. Рәсми очрашу.* □*Мин килүгә, Дәүләтшин рәсми рапорт бирде.* И. Гази. *Тангатаров бу эшнең рәсми ягын башкаруны үз өстенә күтәргән иде, ялкынланып сайрады.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Бик тыйнак, салкын, үтә җитди. *Рәсми елмаю. Рәсми тон.* □*Нургали, [Сөләймановны] күргәч, шактый аптырап калды һәм уңайсызланып китте, --- ләкин шунда ук үзен кулга алып, --- салкын рәсми кыяфәткә төренде.* Ә. Еники. | *рәв. мәгъ. Сүзләр авыр вә рәсми бардылар, авыр вә салкын булып, бер-берсе белән өешмыйча калдылар.* Ф. Әмирхан.

3. Легаль; хөкүмәт, администрация, закон тарафыннан рөхсәт ителгән. [*Парижда*] *1200 ләп рәсми „кызыл фонарь“ йорты саныйлар.* Г. Гали. *Болар [төрле хәбәрләр] — рәсми газетаның бер номерыннан алынган хәбәр кисәкләре.* Ф. Әмирхан.

РӘСМИЛЕК *и.* **1.** Рәсми булу сыйфаты. *Тәмәке кабызгач, капитан рәсмилеген югалта төште.* М. Мәһдиев.

2. Эшнең, мәсьәләнең рәсми ягы. [*Рәис*] *тагы бер-бер артлы хөкемнең рәсмилекләрен үтәргә тотынды.* Г. Ибраһимов.

РӘСМИЛӘШТЕРҮ *ф.* **1.** Законлаштыру, рәсми төс (көч) бирү, рәсми форма бирү. *Хатынга [баланың] кәгазьләрен бирделәр, эшне ничек рәсмиләштерү юлларын өйрәттеләр.* Г. Минский. || *күч.* Ныгыту, беркетеп кую. [*Әсманың рәсемен*] *альбом эченә каплап кую — Шакирның үзенә мәхәббәтнең ахыргы җепләре дә өзелгәнлеген рәсмиләштерү шикелле булып күренде.* Ф. Әмирхан.

2. Җитди төс (кыяфәт, тон) бирү. *Мөнәсәбәтне рәсмиләштерү.*

3. Легаль ясау, легальләштерү, законлаштыру. *Газетаны рәсмиләштерү.*

РӘСМИЛӘШҮ *ф.* Законлашу, законлыга әйләнү, закон көченә керү, рәсми форма алу, рәсми төс алу. *Чакрымлык невод арканы чыгып җиткәнче, сәгать-*

ләп эшсез торуның рәсмиләшү кадәресе зарарсыз иде. Ш. Камал.

РӘСМИЯТ *и. иск. кит. к.* рәсмилек. *Кадетлар партиясенең рәсмияте дә иттифакныкыннан артык түгел.* Ф. Әмирхан. *Ахунның җитдияте, рәсмияте [Җәләлне] берьюлы суындырды.* Г. Ибраһимов.

РӘССАМ *и. кит.* Сынлы сәнгать өлкәсендә иҗат итүче художник (рәсем ясаучы, скульптор, график). *Әбүзәр абзый шагыйрь кебек нечкә күңелле, табигатьне рәссам шикелле үлеп яратучы бер кеше булып чыкты.* Г. Әпсәләмов. [*Кызның*] *көч аңкыган тулы, төз гәүдәсен Бөек рәссам мәллә ясаган?* Ф. Кәрим. *Менә рәссам ашыгып дивар бизи.* Һ. Такташ.

РӘССАМЛЫК *и.* Рәссам һөнәре. *Художник мәгънәсендә алынган рәссамлык белән гади бер эштән гыйбарәт булган фотографчылык арасындагы ерак аерма билгеледер.* Г. Ибраһимов.

РӘСҮЛ *и. дини.* Пәйгамбәр, динчеләр ышануынча, алланың җирдәге илчесе. *Рәсүлебез Мөхәммәтнең чәчләре колак йомшагына кадәр төшеп торган.* Ә. Фәйзи.

РӘТ I *и.* **1.** Берсе янына берсе урнашкан, бер-бер артлы яки бер сафка тезелгән кешеләр, әйберләр җыелмасы. *Язгы чәчәкләр белән бизәлгән зур залның бер башыннан икенче бер башына хәтле ике рәт сузылган өстәл өстендәге ашамлыклар инде шактый ашалды.* А. Шамов. *Халыкның алгы рәте, зур магазиннар тезелгән урамга җитәрәк, текә кыяга бәрелгән төсле, кинәт кенә туктады.* К. Нәҗми. || Саф, шеренга. *Ротаның арткы рәтендәге кызылармеец Зариф --- салмак кына атлап бара.* Ә. Еники. || Театр, кино һ. б. ш. урыннарда бер буйга тезеп куелган урындыклар. *Фәйзи бер көн алдан*]*Мохтар белән*] *икәвесенә 13 нче рәткә ике билет алып кайтты.* Ш. Камал. *Алгы рәтләрнең берсендә Катя белән янәшә утырган Газинур байрак тоткан Володяга сокланып карый.* Г. Әпсәләмов.

2. Бер төрле товарлар сату өчен базарда бер буйга урнашкан ларек яки прилавкалар.— *Инде карчыкка нәрсә алыйм икән? — дип бераз уйланып торганнан соң, Габдулла аның өчен җимеш рәтеннән бер кадак хөрмә сатып алды.* Ә. Фәйзи. || Урамның бер ягына тезелеп киткән йортлар турында. *Шул Гәрәй, шул Биктимерләр рәте! Һаман, күр, шул авыл!* Н. Исәнбәт.

3. Берәр нәрсәнең тәртибе, җае, нечкәлекләре. *Төшке аштан соң Мостафа винтовка куллану рәтләрен өйрәнеп шөгыльләнде.* Ш. Камал.

4. *күч.* Юнь, мәгънә, уңай як, файда. *Монда да булмас рәт бик: хөкем итми тик тора, Һич кеше белми телен, „тарт-тарт" диеп тик кычкыра.* М. Гафури. *Күләгә корган булсак та, аның да рәте аз иде.* Г. Ибраһимов.

5. *сөйл.* Мөмкинлек; барлык, байлык. *Кесәмдә әллә ни рәтем юк, шулай да өс-башым рәтләдем.* Ф. Хөсни. *Аш-су әзер, бөтен колхозны сыйларлык рәт бар.* А. Әхмәт.

6. *сөйл.* Чират, нәүбәт. *Үләттән калсак та, рәттән калмаган.* Ф. Бурнаш. *Шулай итеп, әкренләп бер-берсен ега-ега зурларга көрәшергә рәт җитте.* М. Гали.

7. Кемнәр, нинди кешеләр исәбендә, арасында саналу турында. *Билгеле инде, [офицерлар] рус телен начар белүчеләр рәтенә керми.* Г. Әпсәләмов. *Тырыша-тырмаша торгач, Галиулла урталар рәтенә басты.* И. Гази. *Без, доктор, сезнең белән әле ул кадәр „картлар" рәтенә кертә алмыйбыз үзебезне.* Г. Минский.

8. Уңаенда. *Сүз рәтендә бер сүз әйтәм, туктагыз, Читкә чыкты бу җүләр, дип сүкмәгез!* М. Гафури.

9. Инкяр итә торган сүзләр белән килеп, берәр нәрсәнең сыйфат, көч һ. б. ш. яктан начар, зәгыйфь һ. б. булуын аңлата. *Үткән ел әнә шул атлар аркасында сабанның рәте булмады.* Р. Ишморат. *Батырланып карда йөрсәк тә без, Юк икән шул, егет, рәтебез!* М. Җәлил. *Баштарак, яңгырларның рәте булмагач, бераз борчыла төшкән идек.* Ш. Камал.

Рәт(ен) белү — берәр нәрсәнең җаен, тәртибен белү. *Газинур, моңарчы да такта яргалаган булганга, эшнең рәтен белә иде.* Г. Әпсәләмов. **Рәт(е) бетү (китү)** — 1) мөмкинлекләр бетү, тормыш хәле начарлану, таркалу; 2) сәламәтлек начарлану, какшау. *Ашказанының рәте китү.* □ *Балавыздан укмаштырган кебек саргылт чырайлы бу хәлсез картның бүген бөтенләй рәте киткән.* К. Нәҗми; 3) бозылу, сыйфаты начарлану; яраксыз хәлгә килү. *Бакчаның рәте китү.* □ *Яңгыр яуды исә, чапкан ашлыкның --- рәте китә.* Ш. Камал. **Рәт(е) күренмәү** — берәр нәрсәнең булуына өмет баглый алмау, ышана алмау.—[*Сугыш туктагач*] *тормыш рәтләнергә мөмкин,— диде* [*Мохтар*].— *Шулай гына булмаса — булмас, хәзергә бер дә рәт күренми.* Ш. Камал. **Рәт хастасы** — киң таралган эпидемия характерындагы авыру турында әйтелә.— *Дәе шул, хәзер төш авыруы рәт хастасы булып йөри.* Ак юл. **Рәт чыгару** — файдалы, эшкә яраклы нәрсә булдыру, тудыру. **Рәт чыгу** — 1) җае, вакыты туры килү; 2) көтелгән эш, файда булу, берәр нәрсә булу. [*Егетләргә*] *карап торсаң, бер дә рәт чыгар кебек түгел иде үзләреннән. Эш беләктә түгел шул, йөрәктә.* А. Шамов. **Рәте чуалу** — тәртибе бозылу. [*Намазның*] *бөтенләй рәте чуала, яңадан башлап җибәрәсе --- була.* Г. Бәширов. **Рәтен табу** — чарасын табу, җайлау, нәрсәне дә булса ерып чыгу. *Әхмәди кулыннан эш килми торган егет түгел, ничек тә рәтен табар әле.* Г. Камал. **Рәтен җибәрү** — берәр нәрсәне бозу, җимерү. *Эшнең рәтен җибәрү.* **Рәтенә төшенү** — берәр нәрсәнең тәртибен, җаен аңлау, белү. *Шәһәрләрдәге урамнарның рәтенә тиз генә төшенә алмассың.* К. Нәҗми. **Рәткә кертү (китерү)** — 1) берәр нәрсәне тәртипкә салу, тәртипкә китерү. *Кулъязмаларны рәткә китерү;* 2) берәр нәрсәне рәтләү, төзәтү, уңайлау. *Газинур --- урыныннан торды һәм өстен-башын рәткә китерә башлады.* Г. Әпсәләмов. **Рәткә керү (килү)** — 1) тәртипкә салыну, тәртипкә килү. *Квартира рәткә килү. Картотека рәткә керү;* 2) рәтләнү, төзәлү, уңайлану, хәлне, тормышны яхшырту. [*Әсәрдә*] *берәүләр, эшләп-эшләп тә, рәткә керә алмыйлар.* Г. Нигъмәти. **Рәткә салу** — тәртипкә китерү, җайга салу. *Идел үзенең киң юлын тузан, төтен чыгармыйча гына, яр кырыйларын дулкын белән ишеп кенә рәткә сала.* К. Нәҗми.

РӘТ II *рәв. диал.* Саннар янында: мәртәбә, кат, тапкыр. [*Кияүне*] *Бибисара туендагы кебек бишалты рәт кертми җибәрү кирәк иде.* М. Фәйзи. *Бер генә рәт шатландыр син мине — көл дә.* М. Гафури.

РӘТКӘ *рәв. диал. к.* рәттән (2 мәгъ.). *Бу Яңил егете икән, калада өч ел рәткә батыр калып, алтын сәгатьләр алган, ди.* М. Гали.

РӘТЕ-ЧИРАТЫ *җыйг. и.* Берәр нәрсәнең тәртибе, рәте, җае. *Минем тойгыларымның хәзер рәте-чираты юк.* Ш. Камал. *Һичбер нәрсәнең рәтен-чиратын табар хәл юк.* К. Нәҗми. [*Хәйри:*] *Намазын да без укымыйбыз инде. Хәзрәткә ияреп кенә барабыз. Барыбер рәтен-чиратын белмибез.* Һ. Такташ.

РӘТЛЕ *с.* **1.** Юньле, әйбәт (кеше турында). *— Стрельцов, мин сезне рәтле кешегә санап йөргән идем, сез...* [*Соня*], *сүзен бетерә алмыйча, тау астына йөгереп төшеп китте.* И. Гази. *Мин инде бумажныгымның рәтлерәк шпанага элгүен тели башладым.* А. Шамов.

2. Акыллы, төпле, кирәкле, юньле (сүз, фикер һ. б. турында). *Кайткан вакытта без бер генә дә рәтле сүз сөйләшә алмадык.* М. Әмир.

3. Канәгатьләнерлек, нормаль. *Кешенеке шикелле рәтле яшьлеге дә булмады бит* [*Миңнулланың*]. И. Гази. | *рәв. мәгъ. Кешеләргә рәтле яшәү өчен Кирәк булган якты көннәрне Без сугышып һәм корбаннар биреп Алган идек моннан элгәре.* Ш. Маннур. *Ул бүген кич рәтле йоклый алмады.* М. Гафури.

4. Нинди дә булса таләпләргә туры килерлек, җавап бирерлек, канәгатьләнерлек; яхшы. *Берничә ай инде Якубның кулына рәтле газета эләккәне юк иде.* И. Гази. *Сабан ашлыгы чәчелгәнчегә хәтле дә рәтле яңгыр булмады.* Ш. Камал.

5. Тәртипкә китерелгән, яхшы итеп эшләнгән. *Рәтле юллар булмаганлыктан, анда туп, танк шикелле авыр сугыш коралларын йөртү һәм армиягә азык ташу эшләре дә бик читен иде.* М. Гали. [*Лутов Зарифка:*] *Шушы адрес белән Мәскәүдә мине табарсың. Документың, фәләнең рәтледер бит?!* Ш. Камал.

РӘТЛЕ-БАШЛЫ *с. сөйл. к.* рәтле. *Рәтле-башлы кеше очратмау. Рәтле-башлы сүз ишетмәү. Рәтле-башлы кием күрмәү.* □ *Бертуктаусыз Хисмәт биш көн йөрде, Рәтле-башлы йокы күрмәде.* Ш. Маннур. [*Гапсамат*] *үлсә, рәтле-башлы чабата ясаучы да калмый икән.* Х. Кәрим.

РӘТЛӘҮ *ф.* 1. Билгеле бер тәртипкә килү, җайга салыну. [*Зиннуровның*] *йөрәк тибеше тавышы чиста, тамыр тибеше нормаль, температурасы да рәтләнде.* Г. Әпсәләмов. *Бригада приказы буенча, полк озакламый кузгалырга тиеш, ләкин аның уң фланг белән бәйләнеше әле һаман рәтләнмәгән иде.* А. Шамов. || Төзәтенү, кием-салымны, гомумән тышкы күренешне тәртипкә китерү. [*Гөлбикә*] *көзгегә килеп рәтләнде.* Г. Ибраһимов.

2. Җайлану, көйләнү, барып чыгу (эш һ. б. ш. турында). *Тик икенче көнне генә эшләр рәтләнеп китте.* М. Гафури. || Яхшыру, әйбәтләнү (тормыш, көн һ. б.). *Һавалар рәтләнү. Тормыш рәтләнү.* □ *Май актыклары һәм июнь аенда аз-аздан булса да яңгырлар яугалау аркасында, игеннәр ярыйсы гына рәтләнделәр.* Ш. Камал. [*Галиулланың*] *алмалары исәнсау өлгерсә, кесәсенә акча керсә, хәле бераз рәтләнер иде рәтләнүен.* И. Гази.

3. Төрле аңлашылмаучылык, каршылыклар юкка чыгу, бетү; килешү, аңлашу. *Мөнәсәбәтләр рәтләнү.*

4. Терелү, уңайлану, алга китү (сәламәтлек, авыру кеше турында).— *Юк, Миңгата, болай йөрмә син, Рәтләп инде, савык, эзгә кер.* Ш. Маннур.— *Дни бераз рәтләнгәч, күчү җаен карарга кирәк.* А. Шамов.

РӘТЛӘП *рәв.* 1. Рәт-рәт итеп, рәтләр белән. *Кемнәрдер ишек төбенә рәтләп тезелгән мендәр, сумка кебек юл әйберләрен алып чыкты.* Г. Ибраһимов.

2. Җиренә җиткереп, тәртибе белән. [*Вәсилә*], *келәттә ялгыз елап ята-ята, шешенеп беткән, сүзләрен дә рәтләп әйтә алмый миңа.* Ф. Хөсни. *Яшьтән рәтләп укымагач, баштарак миңа кыенга туры килде.* Ә. Айдар. || Яхшылап, юньләп. *Була бит шулай: күңел никтер борчыла, ә ник борчыла, үзең дә рәтләп белмисең.* И. Гази. *Мин аның соңгы сүзләрен рәтләп тыңлый алмадым.* М. Әмир.

3. Канәгатьләнерлек, җитәрлек дәрәҗәдә. *Төнне дә, рәтләп ашамаган көйгә, урман арасында ачык һавада, яңгыр астында уздырырга туры килде.* М. Гали. *Бүген мин рәтләп йоклый алмадым.* М. Гафури. *Агачлар арасында әле рәтләп кар да эреп бетмәган, ә инде нихәтле чәчәк, нихәтле үлән.* И. Гази.

РӘТЛӘШТЕРҮ *ф.* 1. Аннан-моннан тәртипкә китерү, тәртип булдыру.

2. Аннан-моннан, көч-хәл белән төзәтү, рәтләү (эшләрне, материаль якны һ. б.).

РӘТЛӘҮ *ф.* 1. Билгеле бер тәртипкә китерү; җайга, көйгә салу. [*Ильяс*] *ашыгып-ашыгып кәгазьләрен рәтли, җыйный, кайберләрен бер як читкә алып куя.* Р. Ишморат. *Исхак агай чабата башларга дип юкәләр рәтләп утыра.* Һ. Такташ. || Нәрсәне дә булса уңайлап кую, төзәтү, җайлау. *Каюм тиз генә бишле лампаны рәтләп, ут кабызып җибәрде.* Ә. Фәйзи. *Рабига* [*яралының*] *--- одеял өстеннән ябынган халатын рәтләде.* А. Шамов. || Төзәтү, кием-салымны, гомумән тышкы күренешне тәртипкә китерү. *Ул --- көзге каршына килде, галстугын рәтләде һәм аны кысыбрак та куйды.* А. Әхмәт. *Гыйззәт абый кояш алган гимнастерка чабуларын төзәтте, каешын рәтләде.* Г. Гобәй. *Кыз, --- тузган чәчләрен рәтли-рәтли, ишеккә ташланды, ләкин берәү дә юк иде.* Г. Ибраһимов.

2. Төзәтү, нинди дә булса эшкә яраклы, файдаланырлык хәлгә китерү. *Шәфыйк бабай кыштан туңып калган мичкәләрдәге бозларны чаба, насос куйган, багорлар, баскычлар төягән арбаларын рәтли.* М. Гали. [*Газинур Вәсбия әбинең*] *мичен дә төзәтеп куя, ишек тупсасын да рәтли.* Г. Әпсәләмов.

3. Җайлау, көйләү (эшне, тормышны һ. б. ш.). [*Якубның*] *аннары әнкәсе исенә төште: картайган инде, эшләрне рәтләгәч, үз яныма шәһәргә алып килермен.* И. Гази. *Ничек тә рәтлисе иде* [*Хәлиловның*] *эшен.* К. Нәҗми. || Яхшырту, әйбәтләү. *Ачлык елны җимерелгән тормышны да рәтләми ярамый.* Ф. Бурнаш.— *Ильяс,— диде* [*абыйсы*], *— күрәсең, һәркем дөньясын рәтләү турында кайгырта.* М. Әмир.

4. Аз-маз әйберләрдән әзерләү, нәрсә дә булса юнәтү, әмәлләү. [*Акчаның*] *калганына аяк киеме рәтләдем.* М. Гафури. *Миңсылу, әрле-бирле йөреп, ашарга рәтләп маташа.* Ш. Камал.

РӘТ-РӘТ *рәв.* Рәт (1 мәгъ.) белән, берничә рәт булып. *Элекке кебек җырлап-җырлап урак урасы, рәт-рәт тезелеп, ак җиңсәләр киеп, печән җыясы --- килә.* Г. Ибраһимов. *Кайчакта алар рәт-рәт тезелгән, алтыннан койган сыман сап-сары салам эскертләренә килеп куналар.* Г. Әпсәләмов.

РӘТСЕЗ *с.* 1. Тәртипсез, билгеле бер тәртипкә салынмаган; буталчык. *Рәтсез исемлек. Рәтсез китаплар.* | *рәв. мәгъ. Зинһар, барыгыздан да үтенәм, болай рәтсез шауламагыз.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Җайга салынмаган, еш кына кыенлыклар чыгып торган, авыр (эш, тормыш турында). *Рәтсез тормышыңны рәтләү өчен зарланып йөреп эш чыкмый.* М. Әмир.

3. Нинди дә булса эш өчен җайланмаган, төзәтелмәгән. *Сабаннар рәтсез. Урындыклар рәтсез.* || Берәр нәрсәне булдырырлык, башкарырлык булмаган. *Атларың рәтсез булса, ындырыңда да рәт булмас.* Р. Ишморат.

4. Юньсез, мәгънәсез (кеше турында). [*Кулаев Гөлҗамалга:*] *Малаегыздан миң риза түгел. --- Рәтсез егет булып чыкты.* Ш. Камал.

РӘТСЕЗЛЕК *и.* 1. Тәртипсезлек, тәртипкә салынмаганлык; буталчыклык. *Шау-шу, рәтсезлек бераз басылды.* А. Таһиров. [*Маллар*] *дала туздырып чабыша башладылар. Җылкычы атаның кәефе китте. Ул мондый рәтсезлекне яратмый.* Г. Ибраһимов.

2. Җайга салынмаганлык, авырлык (эш, тормыш турында). *Һәммәбез берәм-берәм авылда эшнең рәтсезлеге --- турында зарлана* [*идек*]. М. Гали.

3. Юньсезлек, мәгънәсезлек. *Кешеләрнең рәтсезлеге җанга тия.*

РӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* 1. Авырлашу, начарлану (эш, тормыш турында). *Эшләр рәтсезләнү. Укулар рәтсезләнү.*

2. Юньсезгә, мәгънәсезгә әйләнү, юньсез, мәгънәсез булып китү. *Әдип үз заманы зыялылары арасындагы төрле катлауның рәтсезләнүен --- күрсәтә.* Г. Нигъмәти.

РӘТТӘН *рәв.* 1. Янәшә; янында. *Актуш төште һәм, су читендәге юеш комда эзләрен калдыра-калдыра, көймә белән рәттән әкрен генә тәпили башлады.* Г. Гобәй. | *хәб. функ. Мирхәйдәр абзыйның өе йортның түрендә — хуҗаның ике катлы өеннән түбәнрәк мунча белән рәттән иде.* Ә. Фәйзи. || Берсе артыннан (яныңа) берсен куеп, тезеп. *Күкрәгендә рәттән өч көмеш медаль таккан кече сержант Комлев хәтта: „Сез бигрәк бәхетле кеше икәнсез",— диде.* Г. Әпсәләмов. *Капкорсак патша барлык сарай хезмәткәрләрен җыеп, рәттән тезеп, дер селкетеп тиргәп алды.* А. Алиш. || Бер рәттә, сафта торып, кемнән дә булса калышмыйча. *Өскә дошман килгәч, Чыдамады аның йөрәге,— Яшьләр белән рәттән Партизанлык итеп, Якты тормыш өчен сугышты.* Ә. Исхак.

2. Бер-бер артлы, берсе артыннан икенчесен. *Ул үзе рәттән берничә хат яҙса да, җавап килмәде дә килмәде.* Г. Бәширов. || Тоташтан, тукталышсыз. *Дунаев тәмәке кабызып, рәттән бер-ике тапкыр бик ләззәт белән суырып җибәрде.* Ш. Камал. *Ике көн рәттән котырган буран бөтен дөньяны --- сылап куйган иде.* Ә. Еники.

3. Бер уңайдан, (нәрсә белән дә булса) бергә (нинди дә булса эшне башкарганда икенчесен дә эшләү турында). *Алар өчен бердәнбер реаль юл авылга кайтып, ныклы хуҗалык төзү һәм шул рәттән бераз агарту эшләрен алып барудан гыйбарәт.* Г. Нигъмәти.

4. Сайлап тормыйча, барысын да, берсен дә калдырмыйча. *Рәттән ашау. Рәттән уку.*

РӘТ-ЮНЬ *җыйм. и.* Кем яки нәрсәнең дә булса мәгънәсе, юне, рәте. *Бик дөрес! Булмады исә рәт-юнең, Ак тарыдан фәркы [аермасы] юк шул энҗенең.* М. Гафури.

РӘХИМ *и.* Мәрхәмәт, кызганучанлык, кешене аяу хисе, аяучанлык, шәфкать. *Синдә һич рәхим юк икән.* Г. Тукай. *Юк, бу ата фашисттан рәхим көтеп булмый инде.* Ә. Еники.

Рәхим ит (итегез) — 1) тәкәллеф белән берәр нәрсә эшләргә чакыруны, тәкъдим итүне аңлата.— *Я, бабай, рәхим итегез, якынрак килеп утырыгыз.* А. Шамов. *Сафа карт Сәхипкә: — Әйдә, шәкерт, рәхим ит, — дип, туры урам як өйгә алып керде.* Г. Ибраһимов. || Килүче кунакларны каршы алу сүзе: хуш киләсез. [*Мансуров*] *сәерсенеп торган Хәйдәргә:— Рәхим ит!— диде.— Минем кунагым бул.* Г. Бәширов; 2) сорауга ризалык, рөхсәт белдереп җавап бирүне аңлата. [*Әбүзәр абзый Гөлшаһидәгә:*] *Сезнең белән махсус сөйләшәсе сүзләрем бар.— Рәхим итегез, Әбүзәр Гиреевич. Мин һәрвакыт әзер.* Г. Әпсәләмов. **Рәхим итеп** — 1) берәр төрле үтенеч белән мөрәҗәгать иткәндә кулланыла: зинһар. [*Доктор:*] *Рәхим итеп, бер чүпрәкне салкын суга манып китерегез әле.* Г. Камал; 2) берәр нәрсә турында тәкәллеф белән сорауны белдерә; 3) *кер. сүз. функ. Бер-ике көннән кайтып җитәчәк, шуннан соң, рәхим итеп, алырга мөмкин булачак.* И. Гази. **Рәхим итү** — 1) рәхимлелек күрсәтеп, үтенечне кире кайтармау, үтәү, башкару, сораганны бирү. [*Сәркәтип кәгазьне алып:*] *Монысы: юлга акчам юк иде, бераз рәхим итмәсләр микән, ди.* Г. Камал; 2) килү, бару (кунакка).— *Сез дә миңа, зур шәһәрләрнең берсенә, бергәләп кунакка рәхим итегез.* Г. Ибраһимов.

РӘХИМЛЕ *с.* 1. Мәрхәмәтле, кызганучан, ярдәмчел, йомшак күңелле, шәфкатьле.— *Ни өчен син безнең Николайны бу хәтле азаплыйсың, ни өчен бераз рәхимлерәк була белмисең?* И. Гази. *Нинди дер рәхимле бәндәләр безне үзләренә алганнар.* Ә. Айдар.

2. Кеше өчен яхшы, игелекле. *Җепшек канатларын җәеп, рәхимле яз килде.* Г. Гобәй.

РӘХИМЛЕЛЕК *и.* Рәхимле булу, шәфкатьле булу, миһербанлы булу.

Рәхимлелек күрсәтү — мәрхәмәт күрсәтү, кызгану, шәфкатьлелек күрсәтү.

РӘХИМ(ЛЕ)ЛӘНҮ *ф.* Рәхимлегә әйләнү, рәхимле булып китү. *Хәятым әллә ничә дәрәҗәдә матурайды, баеды, язмыш тагы рәхимләнде.* Г. Ибраһимов.

РӘХИМСЕЗ *с.* 1. Бернинди дә мәрхәмәт күрсәтми торган; кызганмый торган, каты күңелле, шәфкатьсез. *Рәхимсез куллардан кәрванчылар рәнҗетелгән.* Ф. Бурнаш. *Тешсез Ибрай безнең өчен иң рәхимсез кеше булып санала иде.* М. Әмир. || *рәв. мәгъ.* Кызганусыз, мәрхәмәтсез рәвештә. [*Нәфисә*] *үзенең бодаена җәй буе шулкадәр ияләшкән икән, барабан тешләре бодайны рәхимсез ботарлый башлагач, анда хәтта кызгануга якын бер хис туды.* Г. Бәширов. [*Дәүләтшин*] *көн буе үзалдына сөйләнеп, мәхәббәт җырларын җырлап, чәчәкләрне, үләннәрне рәхимсез таптап, мәҗнүн кебек тилереп йөри.* И. Гази. || Рәхимсезлек, катылык, ачу белдергән. [*Гаязның*] *рәхимсез төс алган кара күзләре миңа туктарга кушалар иде.* М. Әмир.

2. Бик көчле, артык каты (табигать күренешләре турында). *Көз үзе белән салкын җил, кыш рәхимсез суык бураннар алып килгән.* Д. Аппакова. *Актарылды кара болыт, Рәхимсез җилләр исте.* З. Мансур. | *рәв. мәгъ. Кояш иртәдән алып рәхимсез пешерә.* Ш. Усманов.

РӘХИМСЕЗЛЕК *и.* Рәхимсез булу сыйфаты. *Тик дхминең рәхимсезлеге хакында ара-тирә бер-ике сүз кыстыргаладым.* Г. Ибраһимов.— *Дустым! Моннан соң инде синең батырлыгың безне көрәшкә дошман өстенә алып барыр, ул безнең рәхимсезлек һәм үч алу байрагы булыр.* А. Шамов.

РӘХИМСЕЗЛӘНҮ *ф.* Рәхимсезгә әйләнү, рәхимсез булып китү. *Кызның тавышы тагын да рәхимсезләнә төште.* Г. Әпсәләмов.

РӘХИМЧЕЛ *с. сөйл. к.* рәхимле.

РӘХИМ-ШӘФКАТЬ *җыйм. и.* Рәхим һәм шәфкать; хәлгә керү, кызгану хисе.— *Ну, Заһид Сафич, бу юлы инде син миннән рәхим-шәфкать көтмә,— диде* [*Басыйров*]. А. Расих. *Зиннәт хәзер бернәрсәгә дә куанмый да, кайгырмый да, бөтенесенә күзләрендәге боз салкыны аша гамьсез карый, хәтта аңарда үзүзенә дә рәхим-шәфкать юк иде.* Г. Бәширов.

Рәхим-шәфкать күрсәтү — мәрхәмәт күрсәтү, рәхимлелек күрсәтү, кызгану.

РӘХИМ-ШӘФКАТЬЛЕ *с.* Рәхим-шәфкатькә ия булган, кызганучан холыклы.

РӘХМӘТ *и.* 1. Аяу, кичерү, мәрхәмәт. [*Хаҗия:*] *Я ходай, без --- бәндәләреңне рәхмәтеңнән ташлама.* Т. Гыйззәт.— *Я алла, я кәрим, үзеңнең рәхмәтең белән ярлыка инде безнең бар гөнаһларыбызны!* М. Гали. *Бәлки, рәхмәт яңгырыдыр, Яшьнәсен ул, яшьнәсен!* Г. Тукай.

2. *хәб. сүз.* Яхшылыкка җавап итеп әйтелә торган сүз.— *Шулай да котлавыгыз өчен рәхмәт, Фәтхи иптәш.* Ш. Камал.— *Үзегезнең шундый тәрбияле булуыгыз өчен дә һәм балагызны шундый яхшы итеп*

тәрбияләвегез өчен дә рәхмәт. А. Шамов. || *и. мәгъ.* Яхшылык эшләгән, ихтирам күрсәткән, берәр игелекле эш эшләгән өчен зур канәгатьлек белдерү хисе. *Балта остасының рәхмәте иң кадерле, иң кыйммәтле бүләк булып тоелды әминәгә.* Г. Минский. *Тапшыруның иң соңында бер кыз Москва эшчеләреннән килгән бүләкләр өчен үзләренең рәхмәтләрен белдерде.* А. Әхмәт. || Кемнең дә булса эшчәнлегенә, хезмәтенә рәсми уңай бәя. *Дәүләткә ашлык тапшыруның айлык планын тутырып, райком югарыдан рәхмәт алды.* Г. Бәширов.

3. Нинди дә булса тәкъдимне тәкәллефле генә кире кагуны белдерә. — *Сез туктар дип, [бәрәңгене] күп итеп пешердем. — Рәхмәт, Мәрдәнша бабай, соңга калабыз, төн җитә бит.* Г. Гобәй.— *Нихәл, днвәр, әйдә, утыр кереп!— Юк, мин... Рәхмәт. Җәяү күңелле!* Ш. Мөдәррис.

Рәхмәт уку — ихлас күңелдән кат-кат рәхмәт әйтү. *Хәсән, эшләпәсен алып, кызга рәхмәт укыды.* Ф. Әмирхан.

РӘХМӘТЛЕ *с.* **1.** Рәхмәт хисе белдергән. *Чжу карт --- рәхмәтле күзләре белән ераклашып барган Степановка --- карый иде.* А. Шамов.

2. Рәхимле. [*Хәмдия:*] *Минем исемемә көй чыгарган рәхмәтле бәндә кем бу?* М. Фәйзи.

РӘХӘТ *и.* **1.** Материаль муллык, иркенлек; яшәү, эшләү һ. б. өчен бик уңайлы шартлар, мөмкинлекләр. *Алгы көннәрнең рәхәте өчен саф орлыклар чәчәләр.* Г. Ибраһимов. *Зурайгачтын, рәхәт эчендә дә Истән чыкмый балачак.* Ә. Исхак. || *с. мәгъ.* Мул, иркен, әйбәт. [*Майпәрвәз*] *азмы-күпме рәхәт тормышны да татыган, үксезлекнең ачы күз яшен дә эчкән.* Ә. Еники. *Безнең аркабызда Иркен, рәхәт көннәр күрерсез.* һ. Такташ.

2. Күңелле, җанга ягымлы, ләззәтле кичерешләр, сизелмәүләр нәтиҗәсендә туган шатлык, канәгатьләнү хисе, тойгысы; ләззәт, җан тынычлыгы. *Әллә нинди хыялый сурәтләр, хыялый рәхәтләр туалар.* Ф. Әмирхан. *Тәнгә рәхәт биргән көн җилләре, Сөртегез сез аның яшьләрен.* Ш. Маннур. *Менә шунда, бәхеттән шашып рәхәттә йөргән чагымда, мин сине очраттым.* Г. Кутуй. || *с. мәгъ.* Шул хисне, тойгыны белдергән. *Көндез кояш кыздырган; җир, хәзер ягылган мич кебек, рәхәт җылылык бөркн.* Г. Әпсәләмов. *Сәлим үзенең бөтен тәнендә рәхәт талчыгу сизде.* Г. Гобәй. *Хәрәкәтләремдә нинди дер таныш булмаган җиңеллек, уемда рәхәт иркенлек сизә идем мин.* М. Әмир. || *хәб. функ.* Күңелле, яхшы. *Тыныч та, рәхәт тә бу урман эчендә.* Ф. Кәрим. *Зәңгәр күккә карап, үлән өстендә чайрап яту нинди рәхәт!* И. Гази. *Борылырга да урын калмаган бу кечкенә киоскта Нуруллинга күңелле, рәхәт.* А. Шамов.

3. *рәв. мәгъ.* Тыныч, борчусыз; уңай, яхшы шартларда. *Әллә кемнәр һичбер эш эшләмәсәләр дә шат, рәхәт торалар.* М. Гали. *Үз өйләре булгач, [Нәҗия белән Мөстафин] нинди рәхәт торырлар.* Ә. Еники.

Рәхәт(ен) күрү — 1) кемнең яки нәрсәнең дә булса файдасын, яхшылыгын, игелеген күрү. — *Иремнән калган миллионның үзем рәхәтен күрәм.* Ш. Мөхәммәдев. *Сәхибә апак килен рәхәтен күрә башлар.* А. Әхмәт; 2) яхшы яшәү, рәхәтлек кичерү. *Рәхәтен күргәч, михнәтен дә күр.* Мәкаль. **Рәхәт табу** — берәр нәрсәдән канәгатьләнү хисе сизү, ләззәт табу, канәгатьлек кичерү, җанга тынычлык табу. *Күңелем тыныч-лана, җаным рәхәт таба.* М. Гафури. **Рәхәт чигү (сөрү)** — ләззәтләнү, рәхәтләнү; рәхәт яшәү. *Инде килде яхты көннәр эшчегә, Эшләде күп, инде бүген рәхәт чигә.* Г. Камал. **Рәхәттә йөзү** — 1) мул тормышта яшәү; 2) берәр нәрсәдән канәгатьләнү хисе кичерү.

РӘХӘТЛЕК *и.* **1.** Рәхәт булу. *Рәхәтлеген татыйм яшәүнең мин, Горурлыгын тоям кешенең.* Ш. Маннур. *Урман эчендә көн эссесе сизелми, таманча бер рәхәтлек.* С. Рафиков.

2. Рәхәт тормыш, тыныч, мул тормыш. *Бездәгедәй, һәр җирдә Эшче халыклар бергә Тырыша көн күрергә Рәхәтлектә.* Г. Камал. [*Шәрифләрнең*] *рәхәтлекләре озак дәвам итмәде.* М. Гафури.

Рәхәтлек табу — *к.* рәхәт табу. — *Мин баламның көндәлек дәфтәрен язудан, язылганын укудан рәхәтлек таба идем.* Г. Кутуй.

РӘХӘТЛӘНДЕРҮ *ф.* **1.** Рәхәтлек хисе тудыру. *Бу минутлар Рабиганың да күңелен рәхәтләндерә.* А. Шамов. *Минем эчке күлмәгемнең култык астында әйбәтләп тегелгән йөзәр сумлык ике кәгазь һәрвакыт тәнемне кытыклап рәхәтләндерәләр иде.* Г. Ибраһимов. *Су белән изелгән кызыл балчык, аякларга сыланып, аларны рәхәтләндерә иде.* Ф. Әмирхан. || Рухи тынычлык, ял, җан тынычлыгы, ләззәт бирү. *Рәхәтләндерә йөрәкне ирек җилләре.* Г. Камал.

2. Берәр нәрсәне җитәрлек күләмдә бирү, артыгы белән тәэмин итү, кинәндерү. *Корт, ичмасам, балы белән рәхәтләндерә.* Ш. Камал.

РӘХӘТЛӘНҮ *ф.* **1.** Рәхәтлек хисе кичерү, ләззәтләнү, канәгатьлек сизү. *Каты көрәш дулкыннары арасында минем җаным рәхәтләнә, йөрәгем үзенә көч ала.* Г. Ибраһимов. — *Рәхәтләнде дә соң геолог Нарский Бизмән тау табигатендә!* А. Әхмәт.

2. Рәхәтен, игелеген күрү; файдасын күрү. [*Әхмәт:*] *Ярый, ярый, языгыз! Бар нәрсә дә сезгә булсын, рәхәтләнегез!* Г. Камал.

3. *рәв. мәгъ.* **рәхәтләнеп.** Рәхәтлек хисе кичереп. *Нәфисә бүген үзен һәрьяктан хөр һәм иркенрәк хис итә, рәхәтләнеп көлә иде.* Г. Бәширов. *Зур сандык өстенә җәелгән йомшак түшәккә ятканда Габдулла рәхәтләнеп бер киерелеп куйды.* Ә. Фәйзи. || Бик теләп, ихлас күңелдән. *Әледән-әле очрап торган яңа күренешләрдән телсез калган Гаяз миңа рәхәтләнеп кушылды.* М. Әмир.

РӘШӘ *и.* **1.** Эссе көндә җирдән күтәрелгән җылы пар; төтен сыман пар, томан. *Алда, аксыл рәшә эчендә, Бөгелмәнең биек таш йортлары, элеваторы, тегермән биналары, завод трубалары күренде.* Г. Әпсәләмов. *Ераста күгелҗем рәшә җемелди.* И. Гази.

2. Атмосфера катлауларының төрле дәрәҗәдә җылынулары нәтиҗәсендә ачык һәм тын һавада була торган оптик күренеш; бу вакытта горизонт артындагы күренми торган әйберләр һавада чагылып күренәләр; мираж. [*Күлгә*] *карап барасың, барасың, ләкин күпме генә барсаң да, теге күлгә барып җитә алмыйсың. Чөнки ул юк, ул рәшә генә, коры далада алдап-котыртып уйнаклаган эссе шәүлә генә...* Ә. Еники.

Рәшә уйнау — җир өстендәге һава дулкынланып, селкенеп тору. *Рәшә уйный нурда калтыранып, Арыш кырда серкә очыра.* Ш. Мөдәррис.

РӘШӘЛӘНҮ *ф.* Һавада рәшә күренү. *Алда хәзер— Түбән Сарыманның Рәшәләнгән бодай җирләре.* Ш. Мөдәррис.

РӘШӘТКӘ *и.* **1.** Тар такталардан тезеп яки металл чыбыкларны аркылы-торкылы беркетеп эшләнгән корылма. *Тәрәзә рәшәткәләренә төшкән соңгы кояш нурлары да күздән югалды.* А. Шамов. *Искәндәр бу юлы Маратны ятарга кыстамады, мендәрен кровать рәшәткәсенә ипләп куйды да шуңа сөяп утыртты.* Г. Гобәй. || Такта яки металл чыбыклар белән берәр нәрсәне, урынны әйләндереп алган койма, киртә. *Без күпер читенә тотылган рәшәткә янына килдек тә берничә генә секунд суга карап*

тордык. Ф. Әмирхан. *Аэродромның тирәсен тимер рәшәткә белән әйләндереп алганнар.* А. Алиш.

2. Каты ягулык янганда көле аска төшсен өчен куелган челтәр. *Самовар рәшәткәсе. Мич рәшәткәсе.*

◇ **Рәшәткә артына утырту (утыру** һ. б.) — төрмәгә утырту (утыру һ. б.).

РӘШӘТКӘЛЕ *с.* Рәшәткә тотылган, рәшәткә куелган. *Менә тар камераның рәшәткәле тәрәзәсеннән елтыр-елтыр кояш нуры стенада уйный башлый.* Г. Ибраһимов. *Яшел рәшәткәле бакча Ул сезнең бакча иде.* Ф. Кәрим.

РӘШӘТКӘЛӘҮ *ф. сөйл.* Нәрсәне дә булса рәшәткә белән әйләндереп алу, берәр нәрсәгә рәшәткә кую. *Аннан, тора-бара өй артын рәшәткәләп, бакча утыртырга булыр.* Ә. Еники.

РӘҖӘП *и. иск. кит.* Һиҗри елында җиденче ай исеме.

РӨКҮГЪ *и. иск. дини. к.* рәкәгать. [*Хәдичә түти*], *--- бөтенләй онытылып, рөкүгъ урынына сәҗдәгә китеп бара.* Г. Бәширов.

Рөкүгъ итү — баш ию. *Көчем җыйдым да алдында рөкүгъ иттем.* М. Гафури.

РӨХСӘТ *и.* Бер кеше тарафыннан икенче бер кешегә берәр төрле эшне эшләргә бирелгән ризалык. *Мәдинә фронтлар тынгач кына, госпиталь башлыгыннан рөхсәт алып, Казанга кайта.* К. Нәҗми. *Ана баласының шулай әйбәт итеп рөхсәт соравына бик шатланды.* А. Әхмәт. || Шул ризалыкны раслый торган документ. [*Китапны*] *бастырырга рөхсәт тик 1899 елның ахырында гына килә.* М. Гали.

Рөхсәт итегез — 1) берәр нәрсә эшләргә рөхсәт, ризалык сорау.— *Иптәш майор, мөрәҗәгать итәргә рөхсәт итегез.* А. Шамов; 2) нәрсәнең дә булса башлануын тәкәллеф белән белдергәндә кулланыла. [*Зөлфия:*] *„Якты юл" партия оешмасының эшчелыгын ачарга рөхсәт итегез.* Р. Ишморат. **Рөхсәт итү (бирү)** — нәрсәгә дә булса ризалык бирү.— *Әйдәгез, әйдә, сезгә генә читән аша керергә дә рөхсәт итәм.* М. Әмир. **Рөхсәт кәгазе** — язма рәвештә бирелгән рөхсәт, берәр нәрсә эшләргә язма рәвештә бирелгән ризалык. *Булмаса, төрмәгә барып Хисами белән күрешергә рөхсәт кәгазе бирелсә икән, дип ялварган: — Бирелмәс! — диде* [*адвокат Миңлебикә әбигә*]. К. Нәҗми.

РӨХСӘТНАМӘ *и. иск. кит. к.* рөхсәт кәгазе.

РӨХСӘТСЕЗ *рәв.* Рөхсәт бирелмичә, рөхсәт булмыйча, рөхсәттән башка (тыш), рөхсәт алмыйча. *Рөхсәтсез кергәннәрнең кире чыгарылмаганын күргәч, халык берәм-берәм өйгә тулды.* Г. Ибраһимов.— [*Коненко*] *рөхсәтсез атмасын, патронын саклап тотсын.* И. Гази.

РӨШДИ, РӨШДИЯ *и. иск.* Башлангычтан югары (урта) мәктәп. | *с. мәгъ. Мәдрәсәдә рөшди сыйныфлар, ягъни анда төрле авыллардан килгән зур шәкертләр ятып укыйлар.* Ә. Еники.

С

С Татар алфавитында унсигезенче хәреф.

СААМ *и.* Норвегия, Швеция һәм Финляндиянең төньягында, шулай ук СССРда — Кола ярымутравында яшәүче, фин-угор төркеменә караган телдә сөйләшүче халык вәкиле.

САБА I *и. иск.* Капчыкка охшаган тире яки күн савыт, турсык (су, кымыз кебек нәрсә салып йөртелә). *Байның үз кымызы да хисапсыз иде. --- Кардәшлә**ру**лары да һәммәсе турсыклар, сабалар белән килгәннәр иде.* Г. Ибраһимов.

САБА II: **саба җиле** *шигъ.*— иртәнге саф, йомшак җил. *Таң атты. --- Кошлар чыр-чыр килергә тотындылар. Дә аларның кайсылары тырышып-тырышып сайрарга ук керештеләр. Менә саба җиле исте.* Ф. Әмирхан. *Сахраларда йомшак саба җиле исә.* Г. Тукай.

САБАК I *и. бот.* Үлән үсемлекнең төп өлеше: тамырдан югарыгы, яфрак һәм чәчәк чыгара торган үзәге. *Үлән сабагы. Җиләк сабагы. Бәрәңге сабагы. Кукуруз сабагы. Камыш сабагы. Үрелмә сабак.* □ *Өй турында гөлләр үскән, сабакларын кем кискән.* Җыр. *Бер төптән ике сабак — бодайда бик сирәк була торган хәл бу.* Г. Бәширов. || *диал. Ботак. Көн аяз һәм чатлама салкын булды. Агач сабакларына, телеграф чыбыкларына бәс каткан иде.* А. Расих.

Сабак чыгару (җибәрү) — сабагы барлыкка килү (үсемлек турында). **Сабакка утыру** — сабак үстерү (гадәттә башаклы культуралар турында). **Сабакка үсү** — җимеш яки бүлбе бирмичә яисә бик аз биреп, сабагы нык үсү (үсемлек турында).

САБАК II *и.* **1.** Берәр фәннән белем бирүгә багышланган уку сәгате яки вакыты; дәрес (гадәттә мәдрәсә, әлекке мәктәп дәресе турында). *Сабакка бару. Сабакка йөрү.* □ *Тиздән сабак башлана дип Тавыш килә мәктәптән.* М. Гафури. || Гомумән, укукыту. *Алты-җиде яшьлек бер малайны абыстайга сабакка биргәннәр.* Г. Бәширов. *Яз көне җир кипкәч, --- малайлар сабактан туктадылар.* Ә. Фәйзи.

2. Укыла торган дәрес, фән, алына торган белем (мәдрәсә, әлекке мәктәп дәресе турында, шулай ук өлкәннәр телендә). *Тып-тын була класста Сабак укыган чакта.* Ш. Маннур. *Мәктәпкә йөреп сабагыңны тырышып укысаң, күп нәрсәләрне белерсең.* Д. Аппакова.— *Дин сабагыннан соң, яшерен генә, кайбер балаларга урыс сабагы да укытасың икән дип сөйлиләр сине, хәлфә.* М. Гали.

3. Шәкерткә, укучыга эшләргә, үтәргә кушылган бирем, эш (мәдрәсәдә, әлекке мәктәптә яки өлкәннәр телендә). *Сабак ятлау.* □ [*Газиз:*] *Минем сабаклар хәзерләнеп бетмәгән әле, укырга кирәк.* Ф. Әмирхан. — *Кулыңа ал сабагыңны, Булган бит сәгать сигез.* М. Гафури.

4. *күч.* Киләчәк өчен файдалы нәтиҗәсе булырдай, күңелсез яки аянычлы эш-хәл, вакыйга; гыйбрәтле факт, ачы тәҗрибә.— *Моннан болай сабак булсын: ни җитте, ышанычсыз, шикле кешеләр белән чуалма.* Ш. Камал. *Ул вакыйга минем өчен онытылмаслык бер сабак кебегрәк булды.* С. Әдһәмова.

Сабак алу — **1)** хәлфә, мәдәррис, остабикә кебек укытучыдан уку (дәрес тыңлау), белем алу. [*Шәкертләрнең*] *хәлфәләрдән дәрес ала торганнары, кичә калган сабакларын тыңлатып, яңадан сабак алырга керештеләр.* М. Гафури; **2)** *күч.* күңелсез яки аянычлы эш-хәлдән, вакыйгадан, гыйбрәтле факттан, ачы тәҗрибәдән киләчәк өчен файдалы нәтиҗә ясау. *Илгә һөҗүм иткән агрессорларның сабак алуы.* **Сабак баласы** *иск.*— сабакка йөрүче, уку яшендәге бала. [*Яңа ачылган мәктәптә*] *егерме, егерме бишләп сабак баласы булды.* К. Насыйри. **Сабак бирү (укыту, өйрәтү)** — **1)** мәдрәсәдә, әлекке мәктәпләрдә һ. б. ш. җирдә: дәрес яки өй эше бирү. *Сабак бируче хәлфәләр. Остабикә биргән сабакны ятлау;* **2)** *күч.* кисәтү җәзасы бирү: кыйнау, бик ачулану, каты тәнкыйтьләү һ. б. ш.— *Сиңа актив җыелышы биргән сабак аз булган, күрәсең.* Р. Ишморат. **Сабак тыңлату** — хәлфәдән, мәдәрристән, остабикәдән алган сабакны кабатлап, сөйләп күрсәтү. [*Габденнасыйр — улына:*] *Мин балаларның сабакларын тыңлатып, аларга сабак биреп бетергәнче, син шунда утырып тыңлап тор, улым; соңыннан синең сабагыңны карарбыз.* М. Гали. **Сабак уку** —уку, белем алу (мәдрәсәдә, иске мәктәптә, шулай ук өлкәннәр телендә). *Гайникамал — остабикәдә сабак укучы кыз.* Т. Гыйззәт.

САБАКЛАНУ *ф. бот.* Сабак үстерү, сабаклы булу (үсемлек турында).

САБАКТАШ *и.* Бергә сабакка йөргән, бергә укыган кеше. *Харис армиядән кайткан елны ук кичке мәктәпкә сигезенче класска укырга керде. Нәҗия дә сигезенчедә иде. Шулай итеп, алар сабакташлар булдылар.* Р. Төхфәтуллин. *Фәрит өйдә юк. Үзенең сабакташлары — күрше малайлары яныннан кайтмаган.* Ш. Камал.

САБАКТАШЛЫК *и.* Сабакташ булу.

САБАКЧА *и. бот.* Сабактан тармакланып аерылып чыккан кечкенә сабак.

САБАН *и.* **1.** Җир сукалый, сөрә торган авыл хуҗалыгы коралы; сука. *Сабан көйләү. Сабан калагы.* □ *Ул заманда хәзерге кебек җыйнак тимер сабаннарның исеме дә юк, һәркем, зур һәм авыр булганга, агач сабанга дүрт ат җигеп, җирне шуның белән сөрәләр иде.* М. Гафури.

2. Җир сөрү-сукалау эше. *Алар төнгә кадәр булса да эшләп, сабанны бетереп кайтырга уйладылар.* Г. Гобәй. *Кайберәүләрнең бияләре кар эри башлагач та колынлады, язгы сабанга чыккач инде авылда, һәр йортта диярлек, колыннар күренә торган булды.* Г. Ибраһимов.

3. Язгы сөрү-чәчү эшләре. *Мин сабан сукасы белән каты суканы, акча җибәреп, абыйга ышандырып кына эшләтсәм дә, уракка үзем кайтмый булдыра алмадым.* М. Гали.

4. Язгы сөрү-чәчү вакыты, чоры. *Сайрап чыга тургай сабанда.* Ш. Маннур.

5. Яз чәчелеп, шул елны өлгерә торган иген; *рус часы:* яровые. *Сабан бодае.* □ *Гафият авылны чабып узды да сабан басуына килеп чыкты.* И. Гази. *Арышы, сабаны — минем өч дисәтинәгә якын чәчкәнем бар.* М. Гали.

6. *с. мәгъ.* Яз чәчелеп, шул елны өлгерә торган. *Сабан ашлык басуы.* □ *Арыш урагы ике дисәтинә [урдык], сабан ашлык, җитен...* Ә. Фәйзи.

Сабан сөрү — сабан белән җир сукалау. *Бер Үгез көн буенча сөреп сабан, Авылга кайтып килә кичкә табан.* М. Гафури. **Сабан туе** — традицион милли бәйрәм (язгы эшләр беткәч үткәрелә). *Колхозлар оешкач, сабан туйларын язгы эшләр беткәннән соң уздыру гадәте кереп киткән.* Г. Бәширов. *Диңгез кебек иркен, киң болында Кызык та соң сабан туенда.* Н. Исәнбәт. **Сабан тургае** — *к.* тургай (1 мәгъ.). *Кояшның беренче нурлары белән һавага күтәрелгән сабан тургаеның чишмә суыдай челтерәп аккан җыры күңелләрне җилкетә.* И. Гази. **Сабанга керү** — яше җитеп, сабанга җигелә башлау (эш хайваны турында). [*Чабышка килгән ат*] *кечкенә генә, ябык кына бер нәрсә, быел гына сабанга кергән, ди.* Г. Ибраһимов.

САБАНДАШ *и.* Җирләрен бер үк сабан белән, бергәләп эшкәртүче хуҗаларның берсе. *Бу ел без күршеләр белән сабандаш булган идек. Безнең бер ат, аларның өч ат, көйсез агач сабанны шул дүрт ат көчкә генә тарталар.* М. Гафури.

САБАНЧЫ *и.* Сабан белән җир сөрүче. *Ул кулы белән үзләренең алдында җәелеп яткан киң басуны, анда мәш килеп эшләп йөргән сабанчыларны, тырмачыларны, бөтен район җирен күрсәтте.* Г. Бәширов. || *махс.* Трактор белән сөргәндә: сабаннарны көйләп-күзәтеп баручы, шулар өчен җаваплы кеше; *русчасы:* плугарь. *Яшь егет көннәрнең берендә кардәшрәк тиешле Мәсгут абыйсында сабанчы булып йөрергә теләк белдерә.* Соц. Тат.

САБИТ *с., хәб. функ., иск. кит.* 1. Сүзендә, вәгъдәсендә, ниятендә, тоткан юлында: нык, тайпылмаучан, кире кайтмаучан. *Мин сиңа биргән бөек анты мда, вәгъдәмдә сабит!* Һ. Такташ.

2. Башкарган эшендә, хезмәт урынында: нык, какшамас, алып ташларлык түгел. *Сабит булып шаһлыгында Торна бик күп тормады.* М. Гафури.

САБОТАЖ *и.* Эшләгән, боерыкларны үтәгән булып күренеп тә, асылда эшне өзү турында кайгырту; эшне, чараларны астыртын җимерү эше һәм алымы; корткычлык. *Саботаж оештыру. Иске дәүләт аппараты хезмәткәрләренең саботажы. Патша армиясендәге саботаж. Саботаж ясап эшне өзү.*

САБОТАЖЛЫК *и.* Саботаж ясау; эшкә комачаулау, карарларны үтәмәү күренеше; корткычлык. *Алпавыт, саботажлык кылып, җирне чәчми калдырмакчы, халыкны ачлык белән буып алмакчы булган.* М. Шабай. *Баязитов, егерме елга якын хәреф җыючы булып эшләгән кеше, типографиянең саботажлык итүче иске мөдире урынына яңарак кына мөдир итеп куелды.* И. Гази.

САБОТА'ЖНИК *и. сөйл. к.* саботажчы. — *Без сине саботажник дигәнебез юк, җизни.* Р. Ишморат. *Юлда безнең авырулар вагонын вокзалларның саботажник чиновниклары ике урында юри өзеп калдырып, берничә көнне әрәм иттеләр.* Г. Ибраһимов.

САБОТАЖЧЫ *и.* Саботаж ясаучы (аны оештыручы яки шуңа катнашучы).

САБУ I *ф.* Гадәттә аяк-кул киеменең тузган берәр өлешен (башын, үкчәсен, бармакчасын, өс киеменең якасын һ. б. ш.): яңартып эшләү, яңаны тегеп яки бәйләп кую. *Күн итеккә яңа баш сабу.* □ *Ул тузган өек яки бияләй кебек киемнәргә баш сабарга өйрәнеп алды.* М. Әмир. || Аяк-кул киеменең башы, яка һ. б. ш. итеп эшләнгән икенче төсле яки бүтән төрле материалны: эшләп кую, тегеп кую. *Аның тез астыннан бау белән буып бәйләгән тула кунычлы, күн сапкан итекләре дә татар кешесе булмавын --- күрсәтеп тора иде.* А. Расих. *Саурый читек, чуклы башмак, вак-вак атлап яндыра; Яка сапкан, энҗе таккан, бак, үзен зурга [куя].* М. Укмасый.

САБУ II *ф. диал. к.* сабышу (1, 3 мәгъ.). *Миңнулла абзагыз тәмам авыруга сапты.* И. Гази. *Хода күрсәтмәсен байларның елкы ите ашап бирәнгә сабуын.* Ш. Мөхәммәдев.

САБУ III *ф.* 1. Берәүгә узарга мөмкинлек бирә, читкәрәк чыгып тору (юлдан). *Юлдан читкәрәк сабып тору.*

2. Ялгышып, адашып читкә чыгу (юлдан). *Урманда сукмактан сабу. Буранда юлдан сабу.*

3. *сир.* Язу (акылдан). *Гакылымнан тәмам саптым.* Г. Кандалый.

САБЫЙ *с.* 1. Бик яшь, кечкенә (балалар турында). *Сабый кыз.* □ *Дүрт яшьлек сабый баланың, ихтимал, аңсыз рәвештә „мөмкин" дип әйтүе аның --- әтисенә күп нәрсә сөйләгәндер.* М. Җәлил. || *күч.* Бик өстән генә фикер йөртүче; мәсьәләнең, хәлнең асылын аңламаучы. — *Әллә ул мине политикада бөтенләй сабый дип уйладымы?* И. Гази. || *и. мәгъ.* Бәби, кечкенә бала. *Бер яшьлек сабый.* □ *Сабый елмаюы кебек саф булсын мәхәббәтең.* Г. Хуҗиев. *Гөлсем апа алдына алып сөя-сөя юаткач, сабый бераз тыныч ланды.* Г. Гобәй.

2. Сабыйларныкы төсле (чырай, кыяфәт һ. б. ш. турында). — *Бу сабый чырайлы, орчык хәтле генә хатын каян шулкадәр күп белә икән?* Ә. Еники.

3. Сабыйлык елларына туры килә торган (чор, вакыт һ. б. ш. турында). *Нинди ваемсыз, нинди рәхәт булган ул сабый чак!* Г. Бәширов. *Ул шушында, шушы өйдә туган һәм үткәргән сабый елларын.* Ш. Маннур.

САБЫЙЛАНУ *ф.* 1. Сабыйлар, кечкенә балалар кебек кылану. *Сабыйланма әле, зинһар, дип, кырыс кына бүлдерде аны Бугров.* М. Зарипов.

2. Сабыйларга охшау. *Куанычыннан Габделбәрнең күзләре яшьләнде. Алай гына да түгел, тәмам сабыйланып калды ул.* М. Шабай.

САБЫЙЛЫК *и.* 1. Сабый халәте, шуңа хас сыйфатлар. *Усал хатыннарның: „Бигрәк озак йоклыйсыз, ---",— дип чәрелдәүләре аның [көтүче малайның] сабыйлыктан аерылмаган кечкенә йөрәгенә үк булып кадалалар.* М. Әмир. — *Бу сабыйлыгымны шушы көнгә тикле берәүгә дә сөйләгәнем юк иде әле, актык сүзләремне әйттерәсең.* Р. Төхфәтуллин.

2. Сабый чак, балалык. *Сабыйлыгым инде күптән үткән. Егет чаклар бара онытылып.* С. Урайский. *Сабыйлык дәвере илаһи бер күренеш шикелле узып китә.* Г. Ибраһимов.

САБЫН *и.* Суда эреп күбекләнә һәм юу-юыну өчен тотыла торган, каты яки ярым сыек матдә (төрле майлар белән селтеләр катнашмасыннан ясала). *Кер сабыны. Исле сабын. Сыек сабын. Кисәкле сабын. Сабын савыты. Сабын порошогы. Сабын заводы. Сабын кайнату.* □ *Сөлге, сабын тотып, Якуп юынырга чыгып китте.* И. Гази.

САБЫНЛАУ *ф.* Сабын сөртү, сабын белән ышку; сабын сендерү. *Кулны сабынлап юу. Балаларның*

шаярып баскыч аратасын сабынлавы. □ *Ул мунчаласын сабынлап белəкләрен ышкырга тотынды.* И. Гази. [*Байбикə — хезмəтчегə:*] *Сабынны күп бетермə. --- Тəнеңне бер генə тапкыр сабынла. Д мунчала белəн ныграк ышкы.* Ш. Камал.

САБЫНЛЫ *с.* 1. Сабыны булган, сабын катнаштырылган, эчендə сабын эретелгəн. *Сабынлы су.*

2. Сабынланган, сабын сөртелгəн. *Сабынлы мунчала. Сабынлы кул.*

САБЫНЧЫ *и.* Сабын эшлəп чыгаручы яки шуның белəн сəүдə итүче. *Сабынчы Муса агай --- күп елларлардан бирле сабын эшлəп, ун вə унбиш мең тəңкə акча ясаган иде.* Ш. Мөхəммəдев.

САБЫР *с.* 1. Түзем һəм тыныч холыклы; ашыкмаучан, ашкынмаучан. *Сабыр карт.* □ *Сабыр иде, түзем иде* [*Искəндəр*] *Һəм ягымлы иде сүзləре.* Ш. Маннур.— *Апа, сабыр бул... Хəсəн үлгəн...* Э. Еники.

2. Сабырлыкны күрсəтə, чагылдыра торган (рухи хəл, мөгамəлə һ. б. ш. турында). *Сабыр холыклы кеше. Сабыр тавыш белəн эйтү. Мөгамəлəң сабыр булу.* □ *Госман һич тə кызмыйча гажəп ачык, сабыр жаваплар бирə торды.* Г. Ибраһимов.

3. *и. мəгъ.* Сабырлык. *Сабыр белəн тыңлау.* □ *Сабыр төбе сары алтын.* Мəкаль. *Мин үз-үземə инде бөтен сабырымны жуям шикелле тоела башлады.* Ф. Əмирхан.

Сабыр итү — вакытына тикле түзеп, чыдап тору. *Сабыр иткəн морадына житкəн.* Мəкаль.

◇ **Сабыр савыты тулу (ташу); сабыр казаны шартлау; сабыр шартлау** — түземлек, сабырлык бетү. *Бүген ул эчендə яшəгəн тормышның артык тарлыгын, артык кысанлыгын --- бигрəк ачык тойды — шул гади вакыйга сабыр савытын ташыттырды.* Г. Ибраһимов. *Буржуйларның шартлады сабыр казаны.* Г. Камал. *Гел-гел сабыр итмəс бит ул, сабыры шартлар бит.* М. Əмир.

САБЫРАЮ *ф. сир. к.* сабырлану. *Бүгенге Гөлфая без белə торган Гөлфая түгел иде инде. Ничектер сабыраеп киткəн, йөзендə, күз карашында моңсулык һəм ниндидер эчке борчылу ярылып ята.* Г. Əпсələмов.

САБЫРЛАНУ *ф.* Сабыр кешегə əйлəнү. *Ул моңарчы без белгəн Имəли түгел иде инде. Житдиləнде, сабырланды, хəрəкəтləре дə, теле дə шомара төшкəн кебек булды.* М. Əмир. *Ул шактый сабырлана, тыйнаклана төшкəн.* Э. Еники. || Сабыр кыяфəткə керү, рухи тыныçлану. [*Мəжлестə утыручы*] *карт, янында хатыны бар икəнен күргəч, кинəт юашланып, сабырланып калды.* А. Шамов. *Яхшылык — яңа савып куйган күбекле сөт əле. Каймагы өскə чыгар тиз, Тик сабырлан, көт əле!* З. Бəширi.

САБЫРЛЫ *с.* Сабыр (1, 2 мəгъ.), түземле. *Бул сабырлы, түземле.* Б. Рəхмəт. [*Зыя*] *бер кəгазь алды да, мөмкин кадəр сабырлы сүзлəр белəн, --- кыска гына бер хат язды.* Г. Ибраһимов.

САБЫРЛЫК *и.* Сабыр кешегə хас сыйфатлар, түземлелек. *Аның сүзен мин һəрвакыт тыңлый идем, əмма бу юлы тыңламадым, сабырлыгым житмəде.* А. Шамов. *Гафиятулла абзый, бөтен сабырлыгын югалтып, бик яман ярсый.* Г. Əпсələмов.

САБЫРСЫЗ *с.* Сабырлыгы булмаган, түземсез. *Сабырсыз кеше. Сабырсыз хайван.* □ *Мондый чакта ана күңеле сабырсыз була; хат китерүче чыгып китүгə үк, ул үзе Миңсылуга эндəште.* Г. Минский. *Ник, дидем, сабырсыз, Тынычсыз син һаман?* М. Жəлил.

САБЫРСЫЗЛАНУ *ф.* Түземсезлəнү, сабырлыкны югалту. *Мин сабырсызланып:— Зөһрə кайда? — дип сорадым.* Ш. Камал. *Монда килəсе икəнегезне ишеткəч тə, əллə нишлəп сабырсызланып көттем мин сезне.* Ф. Əмирхан.

САБЫРСЫЗЛЫК *и.* Сабырсыз булу хəле; түземсезлек. *Урынсыз сабырсызлык һич ярамас.* М. Гафури. *Сабырсызлык тиз картайта.* Э. Камал. *Латыйфа карчык жəйне бик сабырсызлык белəн көтте.* Х. Садрый.

САБЫШУ *ф. юн. килеш форм. соң.* 1. Сыйфатлардан соң: шул халəткə дучар булу. *Кайгыдан диванага сабышу.* □ *— Гыйшкымнан авыруга сабышып китмəсəм ярар иде.* Ф. Əмирхан.

2. Фигыльлəрдəн соң: сабышкан булып кылану, юри эшлəү. *Ишетмəмешкə сабышу. Йоклаганга сабышып тыңлап яту.* □ *Авырдым, ди Тимербулат, Авырганга сабыша.* М. Жəлил. *Заһит барын да аңлый иде. Ləкин ул, белмəмешкə сабышып, сүзне үенга борды.* А. Расих.

3. Исемнəрдəн соң: шул рухи халəт тəэсиренə бирелү. [*Тимербулат*] *Нигə кайгыга сабышкан?* М. Жəлил.— *Бер ялкаулыкка сабышканга күрə генə шулай икəн ул.* Р. Ишморат.

САВА'ННА *и. геогр.* Сирəк-мирəк кенə куак һəм ялгыз агачлар үсə торган тропик дала (Көньяк Америка, Африка, Азия һəм Австралия жирлəрендə).

САВАП *и. дини.* 1. Дингə ышануçыларча, берəр гадел, игелекле эш һ. б. ш. өчен алла рəхмəте булып киләчəк эжер. [*Артём:*] *Диңгез маякчысы булып яшим. Алладан савап алыр өчен, мөсафирларны каршы алам, озатып калам.* Ф. Кəрим. *Əхмəтша! Син бу төн сəхəр аша; Сəүдəгəрләргə күп ди савабы.* М. Жəлил.

2. *с. мəгъ.* Савап китерə торган, саваплы (1 мəгъ.). *— Үзем дə бик яхшы белəм --- хажга бару савап эш икəнен.* Ш. Мөхəммəдев.

САВАПЛЫ *с. дини.* 1. Савап китерə торган (эш, гамəл һ. б. ш. турында). *Безнең эти əлепне таяк дип белми, ləкин китап сүзləре кыстырып сөйləргə ярата, моны саваплы эш күрə.* Г. Гобəй.

2. Савап китерə торган эш эшлəп савап алуга ирешүче (кеше турында). [*Мулла — миччегə:*] *Шул мичне алла хакына оештырып бирсəң, аллаһы тəгалə үзеңне саваплы итəр, намаз-ниязсыз йөрүеңне дə кичерер.* А. Расих.— *Син фəрештə! — ди* [*егет*] *миңа.— Гөнаһлы булма, дим, тиле! — Юк, ди, бер дə гөнаһ түгел! Саваплы гына булам, ди.* Ш. Камал.

САВУ *ф.* 1. Имчəкне кысып тарта-тарта жилендəге сөтне сыгып агызып чыгару. *Сыер саву. Фермада машина (саугыч) белəн саву.* □ *Берничə жирдə башкорт хатыннары --- бия савып йөриләр иде.* Г. Ибраһимов.

2. Имчəк саугандагы кебегрəк хəрəкəтləр ясап, үзенə таба тарта-тарта чыгарып, жыеп тору (жеп, эчəге кебек нəрсəне). *Эчəге саву.* □ [*Кармагына эре балык эләккəн балыкчы үзенең ипташенə*] *кармак сабын суза.— Тот, төшеп савып алам.* Каз. утл. *Əгəр дə без татар тел гыйлеменең жеп очын эзли китсəк, жепне сава-сава --- Каюм Насыйригa барып чыгачакбыз.* Х. Сарьян.

3. Кан тамырларыннан чыгып, организмның берəр өлешендə таралу, жыелу (кан турында). *Баш миенə кан саву.* □ *Зиннəтнең күзен сугып чыгара язды* [*фашист*]. *Күз төбенə шунда ук кан савып шешеп чыкты.* Ш. Маннур.

4. *күч. сөйл.* Берəр кешене яки урынны жинел табыш чыганагы итеп файдалану, аннан табыш-файда алып тору. *Иркə егетнең ата-анасын савуы.* □ [*Галлəм хажи — Сəүбəнгə:*] *Бераз савып чыгып булмасмы дип килгəнсеңдер.* Ф. Хөсни. [*Мəликə — ирену:*] *Ул кəнтəе синең тирəдə чытлана икəн əле. Кесəңне саварга тели торгандыр.* А. Шамов.

САВЫГУ *ф.* Чирлəүдəн, авырту-сызлаудан туктап, сау хəлгə кайту. [*Фəрхəт*] *ничек тə терелермен дип өметлəнə. Иптəшləре дə аны тиздəн савыгырсың дип юаталар.* Г. Хуҗиев. *Гажəпləнмə, доктор, күреп*

кызның Дару эчми кинәт савыгуын. М. Җәлил. *Көз көннәре килгәч, түтәйнең күзләре дә савыкты.* Ш. Маннур.

САВЫКТЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* савыгу. || Сау хәлгә кайтару. *Яралыны савыктыру.* □ *Анасы да, атасы да бөтен көчләрен куеп улларын тизрәк савыктырырга --- тырыштылар.* Ә. Фәйзи. *Улының күзләре турында сүз кузгалса, әнисе өметсезләнеп кул селти, берничек тә савыктыра алмаулары турында сөйли иде.* Каз. утл.

2. *күч. кит.* Яхшырту, нормальләштерү (мөнәсәбәт, хәл, шартларны). *Хезмәт шартларын барлык чаралар белән савыктыру. Дәүләтара мөнәсәбәтләрне савыктыру.*

САВЫМ I *и.* 1. Бер савуда яки мәгълүм бер вакыт эчендә алына торган сөт, шуның күләме. *Атналык савым. Савым графиклары.* □ *Чөгендер күп бирелгәндә сыерларның савымнары да арта.* А. Расих. [*Кайгылы Хәбирәнең*] *кулыннан эше төште. Савымы бермә-бер кимеде.* М. Хәсәнов.

2. Саву эше. *Сыерларны кичке савымга хәзерләү.* □ [*Салих*] *бүген таң атканчы ияр өстеннән төшмәде. Күрәнле ерганак буенда төн чыкты. Җәйләүгә сыерларны иртәнге савымга гына алып кайтты.* Г. Мөхәммәтшин.

3. *с. мәгъ.* Саудыра, сөт бирә торган (сыер, бия һ. б. ш. хайван турында). *Бозаулардан яхшы савым сыерлар үстерер өчен аларны дөрес итеп тәрбияли белергә кирәк.* Ә. Еники. [*Җәйләүдә*] *барлыгы илледән савым бия бар иде.* Г. Ибраһимов.

САВЫМ II *и. махс.* Җеп үлчәү берәмлеге: тегәрҗептә — бер бөртеккә, тырмага озаткан җептә — өч бөртеккә, киләпле җептә дүрт бөртеккә тигез.

САВЫМЛАУ *ф. махс.* Савымнар (II) белән санау, ничә савым икәнен билгеләү (җепнең).

САВЫМЧЫ *и. кит.* Сыер саву эшендә эшләүче.

САВЫР *и.* 1. Ат сыртының арткы өлеше, янбаш тирәсе. [*Гобәйдулла*] *йөкне казылмага төшергән атының савырына имән күсәк белән кундырып, имгәтеп ташлады.* Г. Ахунов. *Аргамакка менсәң — мен сикереп, ат савыркайлары селкенсен.* Г. Тукай. || Кешедә: янбашның арткы өлеше, йомшак җир. *Беләсеңме, нигә [җәяү йөргәндә] шулай тиз арыйсың син? --- Эшләми үскәнгә. Җир сөрмәгән, урман кисмәгән, кар көрәмәгән син. Гел өстәл арты да парта тирәсе. Менә шуңа күрә дә синең савырларың чүпрәк шикелле шәлперәеп кенә тора.* Г. Бәширов. [*Хатын*], *француз үкчәләрен тротуар ташларына бәрә-бәрә, тулы савырларын калтыратып, чайкала-чайкала китеп барды.* К. Тинчурин.

2. Ат савыры тиресеннән эшләнгән күн.

3. *с. мәгъ.* Шул күннән тегелгән, эшләнгән. *Савыр читек.*

САВЫРЛАУ *ф.* Савыр күне куеп эшләү (аяк киемен).— *Улының аягындагы читеге кай тава! Савырлап каеган өр-яңа читек, ә?!* Ә. Фәйзи.

САВЫРЛЫ *с.* Савыр күне куеп эшләнгән (читек һ. б. ш. турында). *Савырлы читек урынына тупас итек кия чәген уйлап,* [*Вахитның*] *йөрәге калтыранып китте.* М. Гафури.

САВЫТ *и.* Түгелә-чәчелә торган һ. б. ш. нәрсәләрне салып саклау-йөртү әйбере. *Кара савыты. Шикәр савыты. Су савыты. Чүп савыты.* □ *Сәхнәгә, кызу атлап, кулына җиләк җыя торган туз савыт тоткан Сафура килеп керә.* А. Әхмәт. *Бераз җиләк җыйдык та, савытларны ярты иткәч, агач төбенә бераз утырып, тәмле генә итеп ашап алдык.* М. Гали. || Аш-су салып йөртә торган тәлинкә. *Песи савыты.* □ *Мәрьямбикә өстәлдән ашны, савытларны җыйнап алды.* Г. Ибраһимов. [*Ят эт*] *Акбүзнең оясы янына килеп, савыттагы инде бозланып өлгергән ашны кимерде.* Г. Гобәй. || *сөйл.* Саклагыч тартма, тышча, футляр һ. б. ш. *Күзлек савыты.*

САВЫТЛЫ *с.* Савыты булган; савытка салынган. *Өстәл өсте --- шоколадлар, савытлы конфетлар, кәрәзле баллар белән тула.* Ф. Әмирхан. *Хәлвәфрүш, башына савытлы хәлвә күтәреп, патша сарае янынан уза.* К. Насыйри. *Җамали, кулындагы савытлы суын идәнгә куеп, смирно басты.* М. Гали.

САВЫТ-САБА *җый. и.* Түгелә-чәчелә торган нәрсәләрне салып саклау-йөртү өчен булган (гадәттә вак) савытлар. *Савыт-саба шкафы. Кунак савыт-сабасы. Аш-чәй савыт-сабасы. Агач савыт-саба. Савыт-саба юу.* □ *Аның өстәлендәге ашамлыклары, савыт-сабалары да үзе кебек чиста, нәфис.* Ә. Еники.

САГА[1] [сағa] *и. махс.* Аткы (таяклы, шакмаклы уенда — бәрә торган таяк, тәпәч; кузналы уенда — гадәттә әрерәк, авыррак кузна). *Малайлар, ике партиягә бүленеп, өй каршындагы тигезлектә шакмак уйныйлар. --- Бер як сага тондырганда, икенче як, күзләрен тасырайтып, уен кагыйдәләрен бозмыйлармы кайгәрләр дип, карап тора.* И. Гази.

САГА[2] *и. әд.* Борынгы Скандинавия һ. б. кайбер Көнбатыш халыкларының әдәбиятында: батырлар турында хикәят, проза дастаны.

САГАЛАУ *ф.* Тотып алу, фаш итү кебек максатлар белән, яшереп, сиздерми генә күзәтү, көтеп тору.— *Мин уңаен сагалап тордым-тордым да кеше күрмәгән арада шул кендекне җиң эчемә тыгып сыздым.* Г. Ибраһимов. *Басу капкасының баганасы төбендә нәрсәдер сагалап утырган соры песи Сәлимнәрне күргәч --- читән астына кереп югалды.* Г. Гобәй. *Мәликә, аның* [*тавыкның*] *кайда йомырка салганын белергә дип, берничә көн сагалап йөрде.* А. Шамов. || Саклау, күзәтү, карау. *Мәликә апа белән Нәсимә исә аны* [*авыруны*] *бер генә сәгатькә дә ялгызын калдырмыйча, алмаш-тилмәш сагалап утыралар иде.* К. Нәҗми.

САГАЛДЫРЫК *и.* Йөгәннең ияк асты каешы.

САГАЮ *ф.* 1. Саклык-сизгерлек тойгысын, игътибарны көчәйтү. *Кинәт нәрсәдер кыштырдап куйгандай булды. Корбангали карт сагаеп тыңлап тора башлады.* Г. Иделле. *Яшел капчыктан чыккан тәмле ис борынын ярып кергәч тә төлке башын югалтмады. Киресенчә, сагайды гына.* Г. Мөхәммәтшин. *Күп сөйләшсә кеше, сагаям мин, әйтер сүзе юктыр, күрәсең!* Ш. Галиев.

2. Сак булуны белдерә башлау (тавыш, чырай һ. б. турында). [*Фәтхи*], *уйларын бер урынга җыярга телләгән сыман, тагын җитдиләнде, тавышы да сагайды.* Г. Бәширов.

САГАЮЛЫ *с.* Сак, сизгер; саклыкны белдерә торган. *Аның хәрәкәтләре сагаюлы һәм серле, чын каракларныкыча иде.* Г. Ахунов. *Закир аганың колагы һәрвакыт сагаюлы. Рәхим белән сөйләшкән арада да ул әледән-әле күрше басудагы комбайн тавышын игътибарга алып торган иде.* М. Шабай.

САГЛАМ *с. иск. кит.* Таза, нык, чыдам. *Саглам карагайлар шартлап ярыла* [*суыктан*]. Д. Фәтхи. || Куәтле, көчле, ныклы. *Саглам халык.* □ *Камал паша хәрәкәте бу — төрек милләтчелегенең бүгенге иң саглам һәм иң самими хәрәкәте.* Ф. Әмирхан.

САГО *и.* Кайбер пальмаларның крахмалыннан эшләнә яки шуңа охшатып бәрәңге һәм кукуруз крахмалыннан ясала торган ярма. *Сагo кушып балык бәлеше пешерү.*

САГЫЗ *и.* 1. Ылыслы үсемлекләрдә: агып чыккач куера торган, ябышучан-сузылучан, исле, үзле сыекча матдә. *Чыршы сагызы. Нарат тактадан сагыз исе килү. Карагай сагызын җыю.* || Шундый сыекчаны

кайнатып ясаган һәм чәйнәү өчен кулланыла торган пластик әйбер. *Хатыннар сөйләшергә сүз тапмаса, сагыз чәйни диләр.* А. Шамов.

2. Кайбер агач бөреләрендә була торган ябышучан, үзле матдә. *Агач бөресенең сагызы кулга ябышу.* || Кайбер үләннәрдә: ябышучан-сузылучан, үзле сыекча, куе сүл. *Билчән сагызы.*

3. Колак куышлыгында барлыкка килә торган саргылт, майлы матдә. *Колакка сагыз утыру.*

4. *күч.* Артык еш мөрәҗәгать итеп яки әрсезләрчә куштанланып-ялагайланып яисә һаман бәйләнеп торучы. *Нинди сагыз бу Мингаян түти, кунакка тын алырга да ирек бирми; --- бер алдына, биш артына төшә.* С. Рафиков.

САГЫЗАК *и. к.* сагыз (4 мәгъ.). [*Солдат — сорау бирә-бирә төпченүче иптәшенә:*] *Бәйләнчек, сагызак!* Каз. утл.

САГЫЗЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сагызлау. || Сагызлыга әйләнү, үзенә сагыз (1, 2 мәгъ.) буялу, сылану яки сеңү. *Нарат кискәндә пычкы сагызлану. Утау утаганда кул сагызланып бетү.* □ *Соңгы учмасына башын салып Буразнада тапты баласын. --- Сагызланган үтмәс урак алып Үзе „әби" булды үзенә.* Ф. Кәрим.

2. Сагызга (1, 2 мәгъ.) әверелү яки сагыз сыман хәлгә килү.

3. Сагыз (3 мәгъ.) утыру. *Колак сагызлану.*

4. *күч.* Артык еш мөрәҗәгать итеп, әрсез куштанланып яки һаман бәйләнеп тору. *Сүс өмәсендә тана колак Хөснулла Хәбире бик сагызлана башлагач, Банат тегеңә киле сабы белән кундырган.* И. Гази. *Хөрмәт күрсәт,— яраклашма, сагызланма.* Н. Арсланов.

САГЫЗЛАУ *ф.* Сагыз (1, 2 мәгъ.) сылау, йоктыру; өстен сагызлы итү.— *Сызгычны* [*скрипкәгә сызып*] *сызгырта торган хәйләне мин генә беләм дип йөри идем, аны син дә белеп алгансың икән! Син аны сагызлагансыңдыр әле?* Ә. Фәйзи.

САГЫЗЛЫ *с.* **1.** Сагызы (1, 2 мәгъ.) булган, сагыз бирә торган. *Сагызлы агачлар. Сагызлы утынның яхшы янучан булуы.* □ *Ул бигек наратның сагызлы кәүсәсенә килеп сөялде.* Л. Ихсанова. *Тирә-якта сагызлы бөреләрнең яки юкә чәчәкләренең хуш исе аңкый шикелле тоела.* А. Расих. || Сагызланган, сагызга буялган. *Сагызлы кулны керосин белән юу.*

2. *күч.* Бик сыланып ябыша торган. *Юл пычрак. Тарантас тәгәрмәчләренә уралган сагызлы балчыкның авырлыгы арта бара.* К. Нәҗми.

САГЫМ *и. сир. к.* мираж (1 мәгъ.).

САГЫНДЫРГЫЧ *с.* Искә төшеп сагындыра торган. *Сагындыргыч минутлар. Сагындыргыч урыннар.* □ *Һәр усакта калган үткән көннән Сагындыргыч матур истәлек.* М. Җәлил.

САГЫНМАКЛЫК, САГЫНМАЛЫК *и.* Сагынганда карар өчен булган истәлек әйбере. *Сагынмаклыкка йөзек бүләк итү.* □ *Хатлар язган Корбан аңарга, Сагынмаклык итеп кararга.* Ш. Маннур. *Ул рәсемнәр хәзер шул күңелле көннәр турында бер сагынмалык, кадерле истәлек булып калды.* С. Әдһәмова.

САГЫНУ *ф.* Элек күрелгән яки белгән берәр нәрсәне, кешене яки үткән хәлне уңай ягы белән искә төшереп, аны юксыну хисе кичерү. *Яшь чакны сагыну. Туган якны сагыну. Озак ашамаган ризыкны сагыну. Командировкадан балаларны сагынып кайту.* □ *Хатынның күзләрендә исә рәсем аша да сагыну, ирен юксыну моңнары аңкып тора.* А. Шамов.

САГЫНУЛЫ *с.* **1.** Сагыну катнаш (хисләр турында). [*Ана белән кызы арасында*] *каты әрнүле шелтәләр белән бергә сагынулы мәхәббәт үпкәләре түгелде.* Г. Ибраһимов. || Сагынып үткәрелә торган (вакыт һ. б. турында). *Сагынулы көннәр.* □ *Шундый сагынулы минутларның берсендә Гәрәй* [*истәлек актарып укый башлады*]. А. Гыйләҗев.

2. Сагынуны белдерә, күрсәтә торган. *Сагынулы җыр.* □ *— Мәдинә дус, бүген ял көне булудан файдаланып, иртәнчәк сиңа бик сагынулы хат язарга утырган идем.* Ш. Камал.

САГЫНЫЧ *и. сир.* Сагыну хисе. *Күрәсең, ул чаклар хәзер инде Сагыныч булып җырга кушыла.* Ш. Маннур.

САГЫНЫЧЛЫ *с.* **1.** Сагыну катнаш, сагынулы (хисләр турында). [*Сугышчылар*] *әти-әниләре белән бәхетле күрешү минутларына ирешүне өмет итәләр һәм хәзерге минутта шул күрешүне күз алларына китереп, шуның сагынычлы куанычын тоеп торалар кебек.* Ә. Еники. || Сагынуны белдерә, күрсәтә торган. *Сагынычлы хат.* □ *Дусларча сагынычлы сәламемне җибәреп калам.* М. Җәлил.

2. Сагынып көтелә, сагындыра торган. *Сагынычлы бәйрәм.* □ *Сагынычлы язның сыерчыгы, Җырла син яшәү көчен.* Ф. Кәрим.

САГЫШ *и.* Берәр нәрсәне яки кешене нык сагынудан, юксынудан туган күңел төшенкелеге, моңаю, кайгы кебек хис. *Аерылу сагышы.* □ *Сагынулар мине моңлы, ләззәтле бер сагышка батырырлар иде.* Ф. Әмирхан. *Үлем сагышы кебек авыр бу тойгы.* К. Нәҗми.

САГЫШЛАНУ *ф.* **1.** Сагышка бирелү. *Сагышланып җырлау.* □ *Газинур урман кисәргә киткәч, Гөлләр ничектер ямансулый, сагышлана башлады.* Г. Әпсәләмов.

2. Сагышлы (2 мәгъ.) төскә, кыяфәткә керү, сагышны белдерә, күрсәтә башлау. *Аның күзләре сагышланды, тавышы да кинәт йомшарып, бөтенләй моңсуланып китте.* А. Шамов. *Айсылу, Мәрьямнең сагышланып түбән караган ябык йөзенә күз салып, аның кәҗәсен сатарга уйлавының сәбәбен белергә тырышты.* Г. Бәширов.

САГЫШЛАУ *ф.* Сагыш хисенә бирелеп, берәр нәрсәне яки кешене уйлау, кайгырту.— *Әллә юкса, мин әйтәм, башыңа берәр исәп төшеп, шуны сагышлап утырасыңмы дим?* Ф. Бурнаш. [*Ана*] *сугыш мәйданында, кан эчендә Үлеп калган балаларын сагышлый.* С. Рәмиев.

САГЫШЛЫ *с.* **1.** Сагышы булган, сагыш хисләрен кичерүче. *Сагышлы кеше.* □ *Бәлки ул җырны сагышлы әсир үзе уйлап чыгарган булгандыр.* Н. Дәүли. || Сагыш белән бер үк вакытта була торган, шуның белән катнаш (хисләр, уйлар турында). *Яфраксыз агач башларында, өй кыекларында һәм кайбер тәрәзәләрдә кояшның кызгылт шәүләләре чагылып күңелләргә сагышлы уйлар сала.* Ш. Камал. || Сагыш белән, сагыш эчендә үтә торган (вакыт, гомер һ. б. турында). *Йа, нинди озын була иде ул сагышлы төннәр!* Г. Бәширов.

2. Сагышны белдереп, сиздереп торган (караш, тавыш һ. б. турында). *Сагышлы тавыш. Сагышлы сөйләм. Сагышлы күз.* □ *Ник сагышлы йөзләрең?* Ф. Бурнаш. *Алар кубызчы каршына басып, Булат уйнаган сагышлы көйгә кушылдылар.* Ш. Маннур. *Кайгылы иде, Сагышлы иде синең җырларың.* Һ. Такташ. || Сагыш барлыкка килүгә сәбәп була торган. *Сагышлы истәлек.* □ *Бикбулат карт бу сагышлы йортта шуның белән әшен бетереп, чыгып та китте.* Г. Бәширов.

САГЫШЛЫК *и. сир. к.* сагыш. *Ничек кенә булмасын, шундый коточкыч вакыйганы исенә төшергәннән соң, бу минутта аның күзләрендә һичшиксез булырга тиеш булган моңсулыкның, сагышлыкның һәм --- үкенүнең әсәре дә юк иде.* А. Шамов.

САГЫШЧАН *с. сир.* 1. Сагышка (тиз) бирелүчән. 2. Сагышлылыкны һәм сагынганлыкны белдерә, күрсәтә торган (кыяфәт һ. б. турында). [*Марат*] *үзенә бикләнүчән, тирән кичерүчән һәм бераз сагышчан кыяфәттә.* Н. Исәнбәт.

САДА *и. иск. кит.* 1. Аваз, тавыш. *Венгрның садасы Хәнифәгә бер таныш сада кеби ишетелде.* М. Акъегетзадә.

2. Шәкертләрнең үзләре яки бүтән автор тарафыннан язылып, шәкертләр телендә йөргән җыр, декламация һ. б. ш. *Шәкертләр садасы. Сада җырлау.* □ [*Шәкертләр*] *яңа программалар сорап, садалар, марсельезалар әйтеп, мәдрәсә ташлап чыкканнар.* Н. Исәнбәт.

САДАКА *и.* Дини йолаларны үтәү йөзеннән руханиларга бирелә торган хәер. *Без мулла абзыйларның гает садакаларын санаганнарын карап торырга яратабыз. Ләкин анысын күрү бик кыен.* Г. Гобәй. || Гомумән, хәер; акчалата яки әйберләтә ярдәм. *Инде чыгып китәргә генә дигәндә, тоз сипкән бер телем икмәк алып килеп: — Мә, улым, авылны чыкканда берәр әткә бирерсең, юл садакасы булыр,— диде* [*әнисе*]. Ф. Хөсни.

САДАКАЧЫ *и.* Садака алучы, җыючы.

САДИЗМ *и. к.* садистлык. *Ерткычлык һәм садизм аның* [*фашистның*] *иң яраткан эшләреннән иде.* Ш. Маннур.

САДИСТ *и. кит.* Ерткычларча җәзалаудан тәм, ләззәт табучы кеше.

САДИСТЛЫК *и. кит.* Садист кешегә хас сыйфатлар.

САДӘ *с. кит.* Бик гади. *Бу өйнең эчендәге әйберләр дә тегендәгегә караганда садә иде.* Г. Ибраһимов. *Авылның табигый, керсез күренешләрен, садә тормышын шәһәрнең чуарлыклары белән алмашасым килми.* М. Фәйзи. || Эчкерсез, саф күңелле. *Балаларча садә караш.* □ *Аның дулкынланудан тагын да матурлана төшкән сөйкемле йөзендә табигый бер дәрт, садә яшьлек куанычы балкып китте.* Г. Бәширов.

САДӘЛЕК *и. кит.* Гадилек. [*Тукай*] *тормышында садәлекне һәр нәрсәдән алда күрә торган кеше иде.* Ф. Әмирхан. || Эчкерсезлек, саф күңеллелек, табигыйлек. *Балалар өчен язылган әсәр, ничшиксез, чынлыклы булырга тиеш. Баланың садәлегенә хыянәт итеп, ни җитте шуны язарга ярамый.* Сов. әд. [*Кызның*] *кыйгач кашларында, тулы алсу битендә, җәядәй сыгылып килгән хисле иреннәрендә, хәтта бераз сипкелле борыннарында да балаларча садәлек һәм гөнаһсызлык күренеп тора.* А. Шамов.

САДӘЛӘНҮ, САДӘЛӘШҮ *ф. кит.* Гадиләшү. *Картлар кушуы буенча, ул мулла булып калган һәм әүвәлге белән чагыштырганда соң дәрәҗәдә садәләнгән вазифаларын үтәп --- яшәгән.* А. Тимергалин. *Дача халкы да бөтенләй бер гаилә шикелле булып беткәннәр, ияләшкәннәр, мөгамәләләре садәләшкән.* Ф. Әмирхан.

САЕГУ *ф.* 1. Сай I (1, 2 мәгъ.) булып калу, сайга әйләнү. *Инеш саегу. Күл саегу.* □ *Тора-бара аның* [*чишмәнең*] *суы саеккан.* М. Галәү. *Гыйльми абзыйның йөзе акрынлап ачыла барды: --- Маңгай җыерчыклары саегып, тигезләнеп калды.* А. Тимергалин.

2. *күч.* Эчендәге әйбере бик кимү, бетүгә якынлашу (баз, бура, азык-төлек саклый торган савыт-саба турында). *Җәй башларына бура төпләренең саегуы. Бал-май кисмәкләре саегу. Ел ахырына кассаның саегуы.* □ [*Язга таба*] *печән-салам эскертләре күзгә күренеп кими, силос базлары саега.* Каз. утл. || Бик кимү, әз калу, бетүгә якынлашу (азык-төлек, эш, акча, акыл, рухи сыйфат һ. б. ш. турында). *Белем саегу. Картайган кешенең хәтере саега башлау. Запас саегу.*

САЕН *бәйл.* 1. Исемнәрдән һәм *-ган* формасыннан соң: „һәр“ дигәнне белдерә. *Атна саен хат язу. Бүлмә саен кереп йөрү. Мәскәүгә барган саен күргәзмәләрдә булу.* □ *Яңгыр явып үткән саен Ямьләнәләр матур дөньялар.* Ә. Ерикәй.

2. *-ган* формасыннан соң: берәр эш-хәлнең дәвам итүенә яки көчәюенә бәйле рәвештә икенче эш-хәлнең көчәю, үсү юнәлешендә үзгәрүен белдерә. *Түбәнрәк төшкән саен, томан куера барды, битләргә сыланды.* Г. Бәширов. *Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен.* Г. Тукай. *Җил көчәйгән саен, дулкыннар да көчәяләр.* Г. Гобәй.

3. *-ган* формасыннан соң: дәвамлылык төсмере белдергән сүзтезмәдә кабатлап әйтелгән фигыльләр арасында килә. *Укыган саен укыйсы килү. Эсседә су эчкән саен эчәсе килү.* □ *Яшәгән саен яшисе килә, һәр кичнең иртәсен, һәр төннең таңын күргән саен күрәсе килә ди алар иләндә.* А. Алиш.

САЕСКАН *и. зоол.* Каргалар семьялыгыннан, канат каурыйлары ак, тавышы шытырдап шыгырдаган сыман өзек-өзек чыга торган кош. *Юл чатындагы куш нарат башында чуар саескан күренеп калды.* Г. Әпсәләмов.

САЖИН *и.* 1. Өч аршынга тигез (2,13 *м*) озынлык үлчәве берәмлеге. *Сажин ярымлы бау.* □ *Уткән ел Михайладан уникә сажин урман алган идем.* Г. Ибраһимов. *Җизниләрнең өе бер ун сажин гына булыр ераклыкта икән.* Г. Тукай.

2. Бер сажин озынлыгы махсус җир үлчәү таягы.

САЖИНЛАУ *ф.* Сажин белән үлчәү.

САЖИНЛЫ *с.* 1. Сажин озынлыгындагы. *Сажинлы таяк.*

2. Сажин белән үлчәнгән.

САЗ I *и.* 1. Өстенә су чыгар-чыкмас яки чыгып торган баткак җир. *Саз үләне. Саз суы. Саз сасысы. Саз итеге.* □ [*Карамый торганда*], *азгынрак сыерлар, елгага су эчәбез дип барып, сазга төшеп саталар.* М. Гали. *Әкрен җилгә лепердиләр Сазда мүкләр.* Ә. Ерикәй.

2. Артык сулану-юешләну нәтиҗәсендә җебеп баткакка әйләнгән җир, аяк асты. *Аз гына яуса да гөрләвекләр ага торган бистә урамнары бүген бөтенләй сазга әйләнгәннәр иде.* К. Нәҗми. *Су ера-ера үкереп елап тырмашучы сирәк машиналар сазга әйләнгән юлларда мескенләнеп, кызганыч булып калалар.* М. Шабаев.

3. *күч. гадәттә тартымлы форм.* Торгынлыкка төшкән яки артта калган, яңалыкка каршы булган даирә, тормыш һ. б. ш. *Вак тормыш сазында батып калмас өчен тырышу.* □ *Сәлимов бөтен гомере буенча хатыннарны вак, түбән мещан сазыннан чыга алмый дип хурлаучы кешеләрдән иде.* Г. Ибраһимов.

4. *с. мәгъ. к.* сазлы. *Саз җир.* □ *Кар астыннан яңа чыгып килә торган саз балчыкны балтырдан ерып, кышын түгелгән чүп өемнәрен актарабыз.* Ш. Маннур. *Саз вакытында да ул* [*Сиваш култыгы*] *бик үк юаш түгел.* Г. Бәширов.

САЗ II *и. шигъ.* Кыллы уен коралы (думбра, сорнай, дутар һ. б. ш.). *Саз чиртү. Саз уйнау. Саз чалу.* □ *Барча илнең сазлары җырлый бүген бәйрәм ямен.* М. Укмасый. [*Кыз*] *матур тавыш белән җырлый, сазын тарта.* М. Гафури. *Әйдә сыздыр, саз моңнары Тугайларда уйнасын.* Ә. Ерикәй.

САЗА *с. сир. к.* сазаган. [*Байның*] *дәүләтен тартып алдылар, сусыз кабып йөтардай сылу кызы саза калды,— бай егетләрендә кызлар кайгысы калмаган иде.* Каз. утл.

САЗАГАН *с.* Өйләнмичә яки кияүгә чыкмыйча бик озак торган. *Сазаган егет. Сазаган кыз.*

САЗАН *и. зоол.* Карплар семьялыгыннан әре тәнкәле төче су балыгы. *Көн урталарында сазаннар, кырыйга якын килеп, лайлалы балчыкка чумып яталар.* Ш. Камал.

САЗАНАК *и. бот.* Арчаннар семьялыгыннан исертә торган исле, мәңге яшел саз үсемлеге; *русчасы:* багульник.

САЗАУ I *ф.* Өйләнмичә яки кияүгә чыкмыйча бик озак тору. *Мулла асравы килеп керде. Кияүгә чыкмый сазаган кыз ул. Ат чаклы зур, җен кебек усал.* Г. Гобәй.

САЗАУ II *с. к.* сазаган. *Шакир гөнаһсыз яшүсмер түгел, азмы-күпме дөнья күргән сазау егет инде.* С. Сабиров.

САЗЛАМЫК *и.* 1. *к.* сазлык (1 мәгъ.). *Сазламык үләне. Печән чапканда сазламыкны әйләнеп үтү.*

2. *с. мәгъ. к. сазлык* (3 мәгъ.). *Сазламык болынны эшкәртү.* □ *Камышлар уртасындагы сазламык җиргә кереп бер эт баткан иде.* С. Шакир.

САЗЛАМЫКЛАНУ *ф. к.* сазлану. *Уйсу җирнең сазламыклануы.*

САЗЛАМЫКЛЫ *с. к.* сазлы. *Сазламыклы урман. Сазламыклы юл.*

САЗЛАНУ *ф.* Сазга (1, 2 мәгъ.) әйләнү. *Күл сазлану. Болын сазлану. Көчле яңгырдан соң юл сазлану. Озак чистартылмаган чишмәнең сазлануы.*

САЗЛЫ *с.* Өлешчә яки тулысынча сазланган, сазга (1, 2 мәгъ.) әйләнгән. *Сазлы әрәмәлек. Сазлы чокыр.* □ *Әле болай яңгырсыз да җир юеш, хәтта күп урыннар сазлы иде. Яңгыр утырып явып, сөрү эшен туктату куркынычы булганга, Гыймазов хафаланып йөрде.* С. Рафиков. *Ун чакрым калынлыгындагы сазлы, пычрак урман үтәргә туры килде.* М. Максуд.

САЗЛЫК *и.* 1. Сазлы җир. *Күлнең кибә-кибә сазлык булып калуы. Сазлык кошлары.* □ *Бу урманнарның эчендә селкенчәк сазлыклар очрый.* Г. Ибраһимов. *Сазлыкта бакалар бакылдавы ишетелә.* Г. Кутуй.

2. *күч. гадәттә тартымлы форм.* Торгынлыкка төшкән яки артта калган, яңалыкка каршы булган даирә, тормыш һ. б. ш. *Ул бит безгә мәктәп юлын башлап күрсәтеп бирде. Югыйсә без гомергә сазлык эчендә батып кала идек.* М. Гафури. *Ул вак тормыш сазлыгына кереп баткан.* Г. Иделле. *Ялгызлык сазлыгыннан чыгу юлларын белмәгән балыкчы семьяларының тормышлары --- дөрләп китте.* Г. Минский.

3. *с. мәгъ.* Сазланган, сазлыкка әйләнгән; сазлы. *Сазлык җирләр файдаланылмыйча, әрәм булып ята. Алардан да файда алуны күздә тотарга кирәк.* Соц. Тат.

САЗЛЫКЛАНУ *ф.* Сазлыкка әйләнү, сазлану. *Елха болынын куаклыклар, --- Займыш болынын урыны-урыны белән чүп үлән баскан һәм алар сазлыклана башлаган.* Соц. Тат.

САЗЛЫКЛЫ *с.* Сазлыгы булган, сазланган. *Качаклар, бераз хәл алгач, тәвәккәллек белән алга шуыштылар. Д сазлыклы җиргә килеп җиткәч, саз эченнән урманга юл тоттылар.* А. Расих. *Ятып калган бик күп батырлар безгә юл ачып бирделәр. --- Миналы, сазлыклы юллардан иң беренче алар үттеләр.* С. Шакир.

САЗЧЫ *и.* Саз (II) уйнаучы, шуның остасы. *Хан сараендагы сазчылар.*

САИЛЧЕ *и. кит.* Хәерче, теләнче. *Кайсыдыр бер кышны безнең авыл саилчесе Югары Тәкәнештә соранып йөргән.* Ш. Маннур. *Ул үзен ниндидер саилче, хәер сорарга кергән кеше кебек уңайсыз хис итә.* Г. Мөхәммәтшин.

САЙ I *с.* 1. Тирән түгел (су һәм сулыклар, чокырлар, шулай ук савыт-саба, баш һәм аяк киемнәре һ. б. турында). *Сай сулы инешне ерып чыгу. Базны сай гына итеп казу. Сай канау. Салатны сай тәлинкәгә салып бирү. Күлмәкнең кесәсе сай булу. Сай эшләпә. Сай галош.* □ [*Бабай*] *сөрелгән җирне карышлап үлчәп карады.— Сай...— диде. Гәрәйнең сабан тотуын яратмады.* М. Җәлил.

2. Әз яки кимчелекле (акыл, хәтер, белем, тәжрибә һ. б. ш. турында). *Юк, аны сай акыллы дип әйтеп булмый. Төпле сөйли.* С. Баттал. *Яшьләр сай хәтерле булалар шул алар.* Ф. Хөсни.— *Гыйлем ягы сай түгел дисеңме?* А. Тимергалин. || Әз белемле. *Мулла, политикадан сайрак булса да, Курманаев әфәнденең фәлсәфәсен бик тиз аңлады.* И. Гази.

3. *и. мәгъ.* Тирән түгел урын (суда). *Вак балыкларның чуртаннан куркып сайга чыгуы.*

4. *и. мәгъ. диал.* Тугай, үзәнлек, болын култыгы. [*Хатын-кызларга һәм бала-чагага урманның җиләкле урыннарын күрсәтеп йөрүче:*] *Аннан, менә теге сайга төшегез. Мин арырак китеп тагын эзлим.* М. Фәйзи.

5. *рәв. мәгъ.* Сабанны тиешенчә тирәнгә кертмичә (сөрү-сукалау турында). *Сай сөрәләр кайбер сабаннар.* М. Җәлил.

◇ **Сай (сайдан) йөзү** — берәр өлкәдә бик аз белем белән эшләү яки бик өстән генә фикер йөртү. *Карчыгының бу сүзенә каршы Тимери берни дә әйтмәде. --- Сай йөзә дип уйлады.* Г. Бәширов. *Ул сайдан йөзә, әкрен кыймылдый.* Ә. Камал. **Сайга утыру** — сай җиргә туры килеп, аскы өлеше терәлү (көймә, пароход һ. б. ш. турында). *Теге пароход сайга утырганда син шунда идеңме?* Г. Гобәй. *Тоз баржасы сайга утырган.* И. Гази.

САЙ II *и. махс.* Чабатада: башны кайтарып (үреп) бетергәннән соң колаксага кадәр салынган юкәләрнең берсе. *Сай салу. Дүрт сайлы чабата. Юкә тар булганда чабатаның саен күбрәк иту.*

САЙГАК, САЙГА *и. зоол.* Куыш мөгезлеләр семьялыгыннан, куш тояклы, күшәүче дала хайваны; антилопаның бер төре.

САЙГАК [сайғақ] *и.* Идән һ. б. ш. итеп тезеп җәйгән такталар; шул такталарның берсе. *Идәндә йөргәндә кипкән сайгакларның шыгырдавы. Яңа өйгә сайгак җәю. Күпер сайгаклары.* □ *Баскыч сайгакларыннан алып бөтен идәннәре сап-сары итеп буялган.* Ш. Маннур. || *диал.* Идән. *Айгыр ябыла торган сарайның сайгак тактасын алыштырдык.* Ф. Хөсни.

САЙГАКЛЫК *с.* Сайгак өчен дип билгеләнгән (такта турында). *Сайгаклык такталар һәм борыслар китереп аудардылар. --- Күрше корпуста шак-шок ремонт эшләре башланды.* Э. Касыймов. || *и. мәгъ.* Сайгак материалы (такталар һ. б.). *Алган бурабыз тора, түбә калае, түшәмлек-сайгаклык барысы да әзер, өй бетерәсебез бар.* Ф. Хөсни.

САЙЛАНДЫК *с.* Башка ишләрен сайлап алып бетергәннән соң калган; түбән сыйфатлы. *Матбугатыбыз бер төрле дә шигырьгә килмәгән вә мотлака ялган буларак „Шигырьләр мәҗмугасы" дип исем бирелгән сүз сайландыклары вә әдәбият чүбеге илә тулды.* Г. Ибраһимов.

САЙЛАНМА *с.* Сайлап җыелган, яхшырак, өстенрәк дип табылган, иң яхшы дип каралган (күп, ишле нәрсә турында). *Сайланма әсәрләр.* □ [*Дошманның*] *танк армияләре, сайланма пехота дивизияләре Сталинградка ыргылды.* Х. Садрый.

САЙЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* сайлау I. || Сайлап алыну, иң яхшылары дип табылу; аеруча лаеклылар дип танылу. *Без, ирекле илнең көчле егетләре, Сайланып, нәкъ арыслан кебекләре, Барабыз алга табан*

каты басып, Тетрәсен дошманнарның йөрәкләре. М. Гафури.

2. Артык озак, бик җентекләп сайлау.— *Яшьлек ул эзләнү, сайлану дәвере. Син дөрес эшлисең, Шәмсекамәр. Чын күңелең белән яраткан кеше белән генә тормыш корырга кирәк.* А. Әхмәт. *Дни, аны [кызчыкны] иркәләп аркасыннан сөйгәннән соң, --- күлмәген котлап нәрсә генә бирим соң дип, чәй янына куелган балан пештеты, бәрәңге пәрәмәче, төче коймак һәм таба күмәче кебек сыйлар арасында сайлана башлады.* М. Әмир.

САЙЛАНЫШ *и.* Сайлау I (1 мәгъ.) һәм сайлану (1 мәгъ.) нәтиҗәсе. *Табигый сайланыш. Яңа сортлар һәм токымнар китереп чыгаруда ясалма сайланышның роле.* □ — *Урынның уңышлы сайланышын искәртүнең дә зарурлыгы юктыр. Күзе бар кеше күрерлек.* А. Гыйләҗев.

САЙЛАУ I *ф.* **1.** Яхшырагын яки кирәгрәген эзләү-карау яисә аерып алу. *Коенганда суның әкренрәк агымлы урынын сайлау. Сыерчыкларның оя сайлавы. Эш сайлау. Баскетбол командасына озынрак буйлы егетләрне сайлап җыю.* □ *Сөйләгән вакытта әйтергә теләгән әйберен аңлату өчен ачык, аңлаешлы сүзләр сайлый-сайлый ул күбесенчә аптырана.* Ш. Камал. *Кыз егетне, егет кызны Бик яхшылап сайласын.* Җыр. || Өстенрәк, яхшырак, дөресрәк дип табу. *[Казанда] Ленин үзенә революция юлын сайлаган.* Г. Кашшаф.— *Мин кулымнан килгән чараларның иң соңгысын сайладым.* К. Нәҗми.

2. Тавыш биреп, берәр оешма, орган членлыгына яки җаваплы (сайлаулы) хезмәт урынына үткәрү, җибәрү, кую, билгеләү, кертү. *Делегатны ачык тавыш белән сайлау. Бюро составына сайлау. Судьяларны сайлап кую. Авыл советы депутатларын сайлау.* □ *Без барабыз сайларга Үзебезнең советка Ил батырларын.* Э. Исхак. || Членнарын шул рәвешле билгеләп (үткәреп, туплап), төзү (сайлаулы оешманы, коллегиаль органны һ. б. ш.). *Җыелыш президиумын сайлау. Бюроны яңартып сайлау. Стенгазета редколлегиясен сайлау. Халык судларын сайлау.*

САЙЛАУ II *и.* Сайлау I (2 мәгъ.) эше, процессы, акты, кампаниясе. *Сайлау системасы. Сайлау алды җыелышлары. Сайлауга килү.* □ — *Соңгы сайлауда аны [Фәхрине] нигә волбашкармага үткәрмәделәр?* Г. Ибраһимов.— *Җиһанша агай, сине киләсе сайлауда председатель итеп сайласак ничек булыр икән?* Һ. Такташ. || Сайлауга катнашу. *Сайлау хокукы. Сайлау ященә җитү. Сайлау таныклыгы. Сайлау цензы.*

САЙЛАУЛЫ *с.* Сайлау-сайлану тәртибендә генә бирелә-алына торган (хезмәт урыны һ. б. турында). *Сайлаулы вазифа. Сайлаулы урында (мәсәлән, авыл советы председателе булып) эшләү.* || Сайлау I (2 мәгъ.) юлы белән тупланган кешеләрдән төзелә, оештырыла торган. *Сайлаулы органнар (мәсәлән, советлар, партоешма бюролары, халык судлары һ. б.). Сайлаулы оешмалар.*

САЙЛАУЧЫ *и.* Сайлауга катнашучы яки шуңа хокуклы кеше. *Яшь сайлаучы. Сайлаучылар исемлеген төзү. Сайлаучыларның кандидат белән очрашу җыелышы. Депутатның сайлаучылар наказын үтәве.*

САЙЛЫК *и.* **1.** Сай I (1, 2, 5 мәгъ.) булу сыйфаты, күренеше, хәле, дәрәҗәсе.

2. Суда: сай урын. *Көймәне сайлыктан сөйрәп уздыру. Суднолларның сайлыкны әйләнеп үтүе. Вак балыкларның сайлыкта тукланып йөрүе.* □ *Зур гына бер алабуга балыгы бармак кадәрле маймычны иң элек сайлыкка, аннан инде яр буена ук куып чыгарды.* М. Хәсәнов.

САЙРА *и.* Диңгез балыгының бер төре (Тын океанның Ерак Көнчыгыш буйларында яши).

САЙРАР *с.* Сайрый торган, сайраучы. *Яз килә шаулап-гөрелдәп, Сайрар кошлары белән.* Ә. Исхак. *Сайрар былбылдай, туйган сөмбелдәй --- Бәйрәм итик без.* М. Җәлил.

САЙРАТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* сайрау (1, 2 мәгъ.).

2. *күч.* Бик оста уйнау (уен коралын). *Курайны, гармунны сайрату.* □ *Сайрат тальянны!* М. Хөсәен.

САЙРАУ *ф.* **1.** Күңелгә ятышлы музыкаль авазлар чыгарып кычкыру яки сызгыру (кошлар турында). *Сандугач сайравы.* □ *Карлыгачлар, Сайрап очыгыз да Туган илкәйләрне үтегез.* Ш. Маннур. *Тургай ул җәй буе сайрый.* А. Шамов.

2. *күч.* Нечкә (югары) тавыш белән бик матур җырлау. *Мәҗлесләр булганда акыннар Хәятның сайравын сорыйлар, аның җырларын сөеп тыңлыйлар.* Г. Кутуй. || Күңелле, ягымлы итеп сөйләү. *Янымда хатыным, балам шатланышып сайрап утыралар.* Ш. Камал. *Халык анда тату Гөрләшеп, сайрап тора.* Н. Исәнбәт. || Бик оста сөйләү. *Челем карт кызы боларны кайдан белеп бетерде икән, теле телгә йокмый, сайрап тора.* Г. Ибраһимов. || *ирон.* Артык озак, күп сөйләү, такылдау. *Гыйззәтҗан һаман үзенекен сайрый, һаман шул бер биш тиен.* Г. Мөхәммәтшин. *Дусларына ярдәм кулы сузсын, Сайрамасын коры тел генә.* З. Бәшири. || Уйнаучы кулындагы уен коралы, аның телләре-кыллары һ. б. ш. турында: музыкаль авазларны аеруча аһәңле чыгару, аеруча музыкаль яңгырау. *Гармун телләре аның кулында сайрап кына тора.* Р. Ишморат.

3. *диал.* Кычкыру; авазлар чыгару (чикерткә, бөҗәкләр турында). *Кайсыдыр почмакта чикерткә сайрый.* К. Нәҗми. *Авыл йокыга чумган. Төнге тынлыкны --- бака тавышы һәм койма-читән артларына поскан чикерткәләр сайравы гына боза.* Э. Касыймов.

САК [сак] I *с.* **1.** Куркыныч булу мөмкинлеген исеннән чыгармаучы; игътибары бик көчле, сизгер. *[Идият] сүзне чамалап кына сөйли, күбрәк тыңларга ярата, гомумән, уяу, сак кеше булырга тиеш.* Ә. Еники. *Ишек кысылып ачылды һәм, киңрәк ачылырга ирек бирми, шунда ук эчтән бер чылбыр тартылды.— Нинди сак кешеләр тора монда,— дип уйлап алды Габдулла.* Ә. Фәйзи.

2. Аеруча сизгер, үткен (тою-сизү органнары турында). *Шулай утырганда Хәлимнең сак колаклары ат абзарының ишеге шыгырдап ябылганын ишетте.* Г. Гобәй. *[Солдатның] күзләре бик сак.* Ф. Кәрим.

3. Милекне бик саклап, бәрәкәтләп файдаланучы, аны кадерләп тотучы. *[Паекны] көне буена җиткерергә кирәк. Берәүләр түзмиләр, берьюлы ашап бетерәләр. Саграк кешеләр өч кисәккә бүләләр дә, бер өлешен иртән ашап, калган ике өлешен көндезгә һәм кичкә калдыралар.* Г. Әпсәләмов.

4. Бүтәннәрнең игътибарын җәлеп итмәскә тырышып, саклык белән эшләнә торган (эш-хәрәкәт һ. б. ш. турында). *Аның хәрәкәтләре бик сак иде.* А. Расих. *Без, автоматларны корып, сак адымнар белән тавыш-тынсыз гына алга барабыз.* Ә. Айдар. || Саклыкны белдереп торган (эш-хәл, сөйләм, тавыш һ. б. турында). *Сак тормыш.* □ *Картрак кешенең йокысы сак була.* Ш. Камал. *Гаяз, берәрсе тыңлап тормасын дигән төсле, сак тавыш белән колагыма пышылдады.* М. Әмир.

5. *рәв. мәгъ.* Сакланып, саклык (1—3,5 мәгъ.) белән, сак I (1—4 мәгъ.) рәвештә. *Сак йөрү. Сак утыру. Бик сак эш-хәрәкәт, мөгамәлә итү. Сак сөйләшү. Сак яшәү.* □ *Ул кычкырып түгел, сак җырлый.* Г. Ибраһимов. *[Сәлим] адымнарын шундый әкрен һәм шундый сак атлый, әйтерсең кош тотарга килүче чуар песи.* Г. Әпсәләмов.

САК [сак] II *и.* 1. Саклау, каравыллау өчен куелган, билгеләнгән кеше, төркем яки кораллы көч. *Сак белән озату. Диңгездәге саклар. Чик буе саклары. Һава сагы.* □ *Матур сарайларга саклар куелган.* Һ. Такташ.

2. Сакчы хезмәте һәм вазифалары; сакчылык посты. *Төнге сакка бару. Чик буенда сакта тору. Сакны алыштырып тору.* □ *Егетләр сафка тезелмичә --- вагоннарына юнәлделәр. Аларның урынын көндез сакка куела торган кечкенә отряд алды.* Ш. Усманов. [*Командир*] *постларны кыскартырга, бары шлагбаум белән штабельләр янында гына ике пост калдырырга кушты.— Д сактан бушаганнарның барысын да— боеприпаслар төяргә!— диде.* Ә. Еники. || *тартымлы форм.* Саклау, саклавы. *Таң беленеп килгәндә тыныч-сыз полк, конвой сагы астында товар вагоннарына ябылып, билгесез якка җибәрелде.* К. Нәҗми.

◇ **Сак астына алу** — берәүне иркеннән мәхрүм итү, кулга алу.

САК III *и. иск.* Юлда капчык урынына йөртә торган зур букча.

САК IV *и.* Хатын-кыз пальтосының бер төре, [*Гайни:*] *Биби абыстай, әле минем сиңа әйткәнем юк бит, мин --- бер сак тектерергә бирдем.* Г. Камал.

САКАЛ *и.* Ирләрнең иягендә һәм яңагында үсә торган чәч сыман йон. *Ир күрке — сакал, сүз күрке — мәкаль.* Мәкаль. [*Көяз шәкерт*] *бүрекне каш өстенәрәк кыңгыр салган, чигә сакалларын җибәреп, ияген кырган.* Ф. Әмирхан. || Хайван яки кошларның кайберләрендә: тамак асты турысыннан сузылып төшеп тора торган озын йоннар, төкләр яки каурыйлар. *Гали аны чирәм белән кунак итә, Кәҗә рәхмәт укый — сакалын селкетә.* Г. Тукай.

САКАЛБАЙ *и.* 1. *сөйл.* Зур сакаллы кеше.— *Бар, сакалбай, кайт та кырын!* Ә. Юныс. *Ишектә больницаның баш врачы — сакалбай Дроздов күренде.* И. Гази.

2. *ирон.* Кәҗә турында.

САКАЛЛЫ *с.* Сакалы булган, сакал үстергән. || Урта яки өлкән яшьләрдәге (ирләр турында). *Зурлар — сакаллы агайлар да — ташкынлы язны, нәкъ элекке еллардагы кебек, дәртләнеп каршыладылар.* А. Шамов. *Хәтта сакаллы абыйлар да укыйлар.* К. Нәҗми.

◇ **Сакаллы сабый** *шелт.*— яше олы булып та, фикер йөртүе, үзен тотуы белән бала-чагага тартымрак кеше турында. *Кара инде сакаллы сабыйны, ташлар белән уйнап утыра.* А. Әхмәт.

САКАУ I 1. *с.* Кайбер авазларны (бигрәк тә *ш, ж, ч, с, з, р, л* тартыкларын) әйтә алмый яки аларны бүтән авазлар белән алыштырып яисә бөтенләй төшереп калдырып, бозып сөйли торган (кеше һәм тел турында). *Сакау балаларның р урынына л яки й әйтеп сөйләшүе.* □ *Берәү, үз тирәсенә уннан артык кеше җыеп, ш урынына с әйтеп, сакау тел, саңгырау аваз белән сөйли иде.* С. Рафиков.

2. Тавышы беткән, сайрау сезоны үткән (күке, сандугач кебек кошлар турында).

САКАУ II *и.* Атларда була торган йогышлы авыру: борын эче һәм йоткылыкның лайлалы тышчасы шешү.

САКАУЛАНУ *ф.* 1. Сакауга әйләнү. *Мин, урманга килгәннән бирле бер дә сандугач тавышын ишетмәгәнгә, әбиләрдән:— Нигә бер дә сандугач сайрамый?— дип сорадым. --- Бака кычкыра башлагач, сандугач сакаулана ич ул,— диделәр.* М. Гали. *Шәрифҗан абый ни өчен сакауланган? Аның ничкайчан болай тотлыгып сөйләгәне юк бит!* Г. Иделле.

2. Сакау (1 мәгъ.) булып кылану, сөйләү. [*Халисә*] *кесәсеннән конфет алып суыра, шуңа сакауланып сөйли.* Г. Зәйнашева.

САКАУЛАУ I *ф.* Сакау тел белән сөйләү. *Теле ачылып килә торган балаларның сакаулавы.*

САКАУЛАУ II *ф.* Сакау II чире белән авырый башлау (хайваннар турында). *Атлар сакаулау.*

САКАУЛЫК *и.* Сакау I булу хәле, сакау кешегә яки кошка хас сыйфатлар. *Өйдәгеләр аның инде бик аз калган сакаулыгын да яшерергә тырышып әйтелгән сүзләрен эш аралаш көлешә-көлешә тыңлап тордылар.* Г. Гобәй.

САКВОЯЖ *и.* Бикләнә торган юл сумкасы. *Сәмигулла абзый базардан яңа план белән кайткан иде. Бәйләп куелган төеннәрне һәм саквояжны күтәреп карады да ул:— Юк, анасы, без чәй-шикәрне саквояжга салганбыз, аларны менә шушы мендәрләр төененә бәйләргә кирәк,— диде.* Ф. Әмирхан. [*Кызның*] *сул кулында кечкенә генә сары күн саквояж.* К. Тинчурин.

САКЛАГЫЧ *и.* 1. Төрле нәрсә җыеп саклау савыты, урыны һ. б. ш. *Болында су саклагыч ясау. Ферма янында бәрәңге саклагыч төзү. Ит саклагыч. Азык саклагычны чистарту.*

2. Төрле әйберне бәрелү-зарарланудан, ватылудан саклау җайланмасы. *Компастагы саклагыч (аның угын бер ноктада туктатып куеп, инәсен зарарланудан саклый). Саклагыч кнопкасы.*

3. *с. мәгъ.* Саклый (1, 2 мәгъ.) торган, шуңа хезмәт итә торган. *Саклагыч күзлек. Саклагыч халат. Саклагыч төс. Электр чыбыгының саклагыч тышчасы кырылу.* □ *Станокларга [автоматларга] саклагыч рәшәткәләр куелган.* Ә. Камал.

САКЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* саклау (1—7, 10 мәгъ.).

2. Үзенне саклау, яклау. *Һөҗүмнән саклану. Җилдән, яңгырдан саклану.* □ [*Шәрәф:*] *Читкә җибәрүләрендә бер хәйлә булмасын дип никадәр сакландым; шулай да ауларына төшкәнмен.* М. Фәйзи. *Газинур, Миңнурыйны уятмаска тырышып, сакланып кына торды да, тиз-тиз киенеп, атлар янына йөгерде.* Г. Әпсәләмов. || Үзеңне тыю, тыеп калу, саклык күрсәтү. *Эчүдән саклану.* □ *Очраган бер кеше сүзенә карап теләсә нинди дуамал адымнар ясаудан сакланырга кирәк.* Ш. Камал.

САКЛАНЫШ *и.* Берәр нәрсәнең сакланып торышы, саклану хәле. *Подвалдагы яшелчәнең сакланышын тикшерү.* □ [*Агроном*] *кайтарылган химикатларның сакланышы белән кызыксынды.* Ш. Усманов.

САКЛАУ *ф.* 1. Куркынычсызлыкны, иминлекне тәэмин итеп тору. *Ил чиген саклау.* □ *Җамали үзен саклау өчен [офицерны] төртеп җибәргән иде, Җамалины унбиш көнгә „дисциплинарный“ командага җибәрделәр.* М. Гали.

2. Югалу, бозылу-зарарланудан имин тоту. *Документларны яхшы саклау. Чәчәкне кыраудан саклау.* □ *Яңгырдан да, салкыннан да Саклый минем шинелем.* Ә. Ерикәй. *Кайбер колхозларда печәнне тозлап кибәнлилләр икән. Черүдән саклый ди.* Ә. Еники. || Берәр максат өчен билгеләү, махсус атап кую (төрле куллану әйберләрен). *Каклаган казны кунак килүгә дип саклау.* □ *Без булган акчаны базар көненә саклап, ул нәрсәләрне [җимешләрне] алып кайтуны зур бәхеттән саный идек.* М. Гафури. *Сугыштан алдагы еллардан калган, Шакирны каршылау өчен саклап тоткан „Магнолия“ исле маен сөртенде [әминә].* Г. Минский. || *у.-вак. килеш. соң.* Югалу, бозылу-зарарланудан имин урында махсус тоту, асрау. *Орлыкны амбарда саклау. Айгырны сарайда саклау. Итне суыткычта саклау.*

3. Бик сак файдалану, кадерләп тоту (кием-салым, корал-дирбияны һ. б. ш.). [*Әнисе:*] *Апаң киемен саклап кия, син алай итмисең шул.* Ф. Әмирхан. [*Эш коралын*] *сорау гына җитми, барын сакълый белергә*

кирәк. К. Тинчурин. || Әрәм-шәрәм итмичә файдалану, бәрәкәтләп тоту (азык-төлек, акчаны һ. б. ш.). *Акчаны саклап кына тоту.* □ *— Әйт Коненкога: рөхсәтсез атмасын, патронны саклап тотсын.* И. Гази.

4. Истә тоту, онытмау (күңел, хәтер турында). *Безнең хәтер кешеләрне аерылышу вакытында ничек күргән булса, шул хәлдә саклый.* Ә. Еники. *Данлы елга! Бик күп истәлекләр Саклый күңел синең турында.* Ә. Исхак.

5. Белдермәү, сиздермәү, сөйләмәү (серне һ. б. ш.). *— Бу серне сез һәркайсыгыз яхшы саклагыз.* А. Алиш. [*Шәүкәт:*] *Каршы түгелсең, шулаймы?* [*Маһирә:*] *Аның сын инде сер итеп сакларга рөхсәт итегез.* Т. Гыйззәт.

6. Карап-күзәтеп тору, күз-колак булу. *Чирәмлектә каз бәбкәсе саклау. Кунакка киткәндә карчыкларны өй сакларга калдыру. Төнгелеккә урманга ат сакларга бару.* □ *Хәзер урманда сыер саклап утырыр хәл юк: урак өсте!* И. Гази. || Кайгыртучанлык күрсәтү, карау. *Аналарны кадерләргә, сакларга кирәк.* А. Шамов. [*Әни*] *— мине карап, төрле бәла-казалардан саклап үстерүче, тәрбия итеп аякка бастыручы.* М. Гафури.

7. Каравыллау. *Колхозда бары да әшкә ярый. Ураkта булдыра алмый икән, әнә, яшелчә саклар.* Г. Гобәй. *Әти әнә шул бакчаны саклау, каравыллау эшен днисә белән миңа тапшырды.* З. Бәширн. || Сак астында тоту. [*Вәзирләр:*] *Алыгыз, кызлар, Бибкәй Солтанны, Сараенда саклагыз аны!* Н. Исәнбәт.

8. Тотып алу һ. б. ш. максат белән сагалау, яшеренеп кенә күзәтү. *Тычканны ярыктан саклап торган мәче кебек, тынымны да алмыйча, тавыкларны күзәтәм.* Ә. Айдар. [*Егет, кызны кисәтеп:*] *Мин сиңа сөйләгән идем ич, алар сине саклыйлар!* Ф. Бурнаш. || *күч.* Берәр нәрсәне яки кешене, күзәтә-күзәтә, түземсезләнеп көтү. *Абый белән без капчыкларыбыздан бәрәңге чыгарабыз да, аны көлгә күмеп, утны болгата-болгата, бәрәңге пешкәнен саклап ятабыз.* М. Гали.

9. *ирон.* Берәр нәрсә яки кеше янында булып, файдасызга вакыт үткәрү турында. *Чәчәргә җирең җитмәгәч, чабарга тугаең булмагач, өстеңә капланырга торган урманнан бер чыбыркы сабы да ала алмагач, нәрсә дип монда гомер буенча Зәңгәр чишмәне саклап ятасың.* Г. Ибраһимов.— *Командир иптәш! Мине үзегез белән алыгыз әле. Шундый вакытта хатынны саклап ятасы килми. Мылтык тота беләм.* Ш. Усманов.

10. Булдыру, тәэмин итү (тәртипне, чисталыкны һ. б. ш.). *Чисталык саклау.* □ *Кавалеристлар, саф саен дүртәр-дүртәр тезелешеп, ләкин саф тәртибен сакламыйча, таркала төшеп, аның артыннан юыртып баралар.* А. Шамов. || Үтәү, тормышка ашыру (әдәп кагыйдәләрен һ. б. ш.). *Традиция саклау.* □ *Мин билгеле бер әдәп сакларга кирәклекне хәтеремнән чыгармыйм.* Ә. Еники. *Режим сакласаң, шушы таушалган әгъзаларың белән дә гомер яшәрсең.* Ш. Бикчурин. || Белдерү, күрсәтү (рухи сыйфатны, халәтне һ. б.). *Мин иптәшем каршында тыйнаклык сакларга тырыштым.* М. Әмир. *Бу күренештән кәеф кырылса да, Сабырлыгын саклап, укытучы Сүз башлады.* М. Җәлил. [*Мостафа*], *Мәдинәгә һичбер ачуүпкә күрсәтмичә, гел яхшы мөнәсәбәт саклап килде.* Ш. Камал. || Дәвам итү (физик, рухи яки иҗтимагый хәлне, халәтне, сыйфатны, форманы һ. б.). *Бердәмлек саклау. Үпкә сакламау. Горурлык саклау. Тигезлек саклау.* □ *Яралылар, җитдилек сакларга тырышып, хәлләрен әйттеләр.* Г. Гобәй. *Бары да тынлык саклый, командалар да пышылдап кына бирелә.* Ә. Айдар. *Усаллык саклый белмим мин.* Г. Минский.

САКЛАУЛЫ *с.* Саклана, сак астында тора торган. *Саклаулы урман.*

САКЛЫ *с. сир.* **1.** Саклана, каравыллана торган. *Төлке саклы бакчага керми.* Н. Исәнбәт.

2. Сак яши торган, сакланучан. *Саклының сагы ятыр, Саксызның башы ятыр!* Н. Исәнбәт.

САКЛЫК *и.* **1.** Сак (1—3 мәгъ.) булу хәле; сак кешегә яки башка нәрсәгә хас сыйфатлар. || Сизгерлек, уяулык. *Саклыкны онытма, Саклык — куркаклык түгел.* М. Сөндекле. *Тирәдәге хәлләр безне шулай саклыкка мәҗбүр итте.* М. Фәйзи.

2. Саклану хисе, уе. *Җиһангир, аягын пычратмас өчен бик саклык белән атлап, җәфаланып бетте.* Г. Ибраһимов. *Баштарак, сакланып, бүрәнәләрне бакчаларга, салам асларына яшереп азапландылар. Соңыннан саклык онытылды: туп-туры урамга, йорт каршына өя башладылар.* И. Гази. || Саклау хисе, уе. *Ак халатлы апа солдатны беләгеннән саклык белән генә тотып көймәгә кертеп утыртты.* Г. Гобәй.

3. Куркынычсызлык, иминлек. *Саклык чаралары күрү.* □ [*Солдатлар*], *саклык өчен үз араларыннан часовойлар куеп, ишек алдында митинг ачып җибәрделәр.* К. Нәҗми. *Дошман, саклык йөзеннән, күрәсең, пулемет уты белән бу тирәләрне дә әледән-әле „тараштыргалап“ тора иде.* Ә. Айдар.

4. *сир.* Саклау-каравыллау өчен махсус куелган, билгеләнгән кеше яки төркем. *Безнең взводны иртән позиция алдына, саклыкны алыштырырга җибәрделәр.* А. Таһиров.

5. Сакчыллык. *Саклыкка өйрәнү. Акчаны бик саклык белән тотучы кеше.*

6. *с. мәгъ.* Иң ахырга саклап калдырган, иң кирәк очракта гына файдалану өчен билгеләнгән. *Саклык ашлык-фәлән дә булмаганга күрә, безнең тормышның матди ягы да* [*начарланды*]. М. Гафури.

Саклык кассасы *махс.*— халык акчаларын сакларга ала торган кредит учреждениесе. **Саклык кенәгәсе** *махс.*— саклык кассасында акча саклаучыга бирелә торган кенәгә.

САКС *и.* Төньяк-көнбатыш Европада һәм Британиядә яшәгән герман кабиләсе вәкиле (сакс кабиләләре башта төньяк-көнбатыш Германиядә яшиләр, V йөздә аларның бер өлеше Британиягә күчеп, болары IX гасырда франклар тарафыннан яулап алына).

САКСАУЛ *и. бот.* Азия чүлләрендә яки ярым чүлдә үсә торган каты вак агач яисә куак (ботактан һәм турыдан-туры кәүсәдән чыккан үренте яки тәнкә-кабырчык сыман яфракларын дөя һ. б. ш. хайван ашый). *Кара саксаул.* □ *Каракомның ак саксауллары турында бик еш уйлыйм.* З. Нури.

САКСОФОН *и. муз.* Җиздән эшләнгән тынлы уен коралының бер төре (тембры белән кларнетка якын).

САКСЫЗ *с.* **1.** Куркыныч турында уйламаучы, саклыкны онытучы. [*Кыз:*] *Акрын, нинди саксыз сез! Сөйләшмәгез, дим!* М. Җәлил.

2. Милектән бик бәрәкәтсез файдаланучы, аның кадерен белмичә эш итүче. *Саксыз хуҗа.*

3. Саклыкны онытып эшләнә торган (хәрәкәт, эш һ. б. ш. турында). [*Госман*] *урам чатларында җыелып яткан пычрак суларга игътибар итмичә, аларны үзенең саксыз адымнары белән чәчрәтә-чәчрәтә китте.* А. Шамов.

4. Саксызлыкны белдерә, күрсәтә торган (эш-хәл һ. б. ш. турында). *Саксыз сүз.* □ *Су чупылдавы колакка чалынып китә. Бу безнең егетләрнең саксыз ишкәк тавышлары шулай ишетелә.* И. Гази.

5. Сакчысыз, каравылчысыз.— *Бакчабыз саксыз калды.* А. Алиш.— *Шундый әһәмиятле объектны саксыз калдыралармы соң?* И. Гази.

САКСЫЗЛАНУ *ф.* 1. Саксызлык күрсәтү, саксыз эш-хәрәкәт итү.— *Нигә ул [командир] ут астында болай саксызланып йөри? — диде блиндажда калган элемтәчеләрнең берсе.* Г. Әпсәләмов.

2. Саксызга әйләнү, саксыз рәвештә эш итә башлау.

САКСЫЗЛЫК *и.* Саксыз кешегә һ. б. хас сыйфатлар. [*Хәйрулла*] *саксызлыгы аркасында бәхетсезлеккә очраган.* А. Шамов.

САКЧЫ *и.* Саклау өчен билгеләнеп, сакта торучы кеше, төркем һ. б. *Казаклар түгел, алпавытның атлы сакчылары иде болар.* И. Гази.

САКЧЫЛ *с.* 1. Куркыныч булу мөмкинлеген исеннән чыгармаучы; игътибары бик көчле, нык; сак.

2. Милектән бик сак файдаланучы. [*Мәрьям:*] *Син ай-һай сакчыл да соң.* [*Нури:*] *Өй җиткерәсем бар бит.* Ю. Әминов.

САКЧЫЛЛАНУ *ф.* Сакчылга әйләнү; сакчыл рәвештә эш-хәрәкәт итә башлау.

САКЧЫЛЛЫК *и.* Сакчыл булу сыйфаты һәм хәле. *Хуҗалык итүдәге сакчыллык.*

САКЧЫЛЫ *с.* Сакчы куеп саклана торган. *Сарай ишеге сакчылы, шуңа кабат бармадым.* Җыр. *Хәдичә, сакчылы капка янындагы будкага кереп, әчкә [губернатор канцеляриясенә] узарга рөхсәт алды.* А. Расих.

САКЧЫЛЫК *җый. и.* 1. Сакчылар, сактагылар. *Батальондагы күтәрелеш иң элек склад сакчылыгын юк итү һәм коралга ташланудан башланачак.* Ш. Маннур. || Саклау-саклану корылмалары, постлар. *Тимерчыбык киртәсенең тышында, чама белән егерме биш метр киткәч, сакчылыкның икенче сызыгы башлана.* Г. Әпсәләмов.

2. Сакчы хезмәте, вазифалары. *Хәтта бу тынлыкка җиңелгәннәр, йоклаганнар каравылчылар да. Оеп, шунда утырып калганнар, Сакчылыкны онытканалар.* М. Гафури.

САЛ *и.* Су белән агызып алып бару яки көймә урынына файдалану өчен теркәп бәйләгән бүрәнәләр. *Сал агызуда эшләү. Елганы кичү өчен берничә бүрәнәне сал итеп бәйләү.* □ *Буксир үтә баржа, саллар тагып.* С. Урайский.

САЛА *и. иск.* Авыл; авыл җире. *Каланы макта, салада тор.* Г. Ибраһимов.— *Сала кешеләре бит без.* К. Нәҗми.

САЛАВАТ *и.* 1. *иск.* Мактап-хуплап яки хәерле юл, уңыш теләп укыла торган дога. *Кари әфәнде үзе, аллы-гөлле тавыш белән кычкырып, салават көйләп тора.* Ф. Әмирхан.

2. *хәб. функ.; сөйл.; юн. килешендәге сүздән соң.* „Хәерле булсын, аның хакында сүз озайтуның кирәге юк“ мәгънәсендә әйтелә (үткән эш-хәл турында). *Үткән эшкә салават.* Мәкаль. [*Файдалы бер очрашу аркасында лекциясен хәзерлексез үткәргән укытучы:*] *Ярар, бер лекциягә салават. Хәерле каза булсын.* М. Госманов.

Салават күпере — кояш нурларының яңгыр тамчылары аша үтеп сынуы нәтиҗәсендә күк йөзендә барлыкка килеп, спектрның җиде төсен дә эченә алган дуга сыман киң сызык. *Яңгыр туктап беткәч, матур гына утлы-яшелле булып, дуга кебек кәкрәеп төшкән салават күпере дә чыкты.* М. Гали.

◇ **Салават әйтү** *иск.*— мактап-хуплап яки хәерле юл, уңыш теләп дога уку.— *Иркенлек илә хөррияткә салават әйтик.* Г. Коләхметов.

САЛА'КА *и. зоол.* Сельдьнең атлантик төрчәсе (аңа караганда ваграк балык).

САЛАМ *и.* 1. Ашлык сабагы. *Минем әле учмаларым зур булмый. Саламнарны тигез тотып, чуалтмый гына ура алмыйм.* М. Гафури. *Ул чыбыктай каты, төп-төз булып үскән арыш саламнарындагы --- башакларны тотып-тотып карады.* З. Бәширн. || *җый.* Сукканнан соң кала торган шундый сабаклар. *Бодай саламы. Борчак саламы. Салам эскерте. Салам көлтәләү.*

2. *с. мәгъ.* Саламнан яки салам катнаштырып эшләнгән. *Салам түшәк. Салам эшләпә. Салам олтырак.* □ *Иге-чиге булмаган озын һәм карлы юл... Бәганалар кала, салам маяклар утырып калалар.* Ф. Хөсни. [*Дошман ташлап киткән блиндажда[матрасларның берсе өстендә салам мендәр һәм камыт кебек итеп төрелгән шинель ята иде.* М. Әмир. || Салам белән ябылган (түбә турында). *Яңа авылда салам түбәле бер генә өй дә күрмәссез.* М. Максуд.

◇ **Салам кыстыру** — *к.* салпы якка салам кыстыру. — *Ярар, ярар, салам кыстырмагыз, зинһар.* А. Шамов. **Салам сыйрак** *гади с.*— нечкә озын ботлы яки гомумән физик яктан йомшак кеше турында. *Чүпрәк итеп чәйнәр иде ул Салам сыйрак Халит морзаны!* Ш. Маннур. **Салам торхан** — һавалы, эреләнеп йөрүче булдыксыз кеше.— *Салам торхан! Нәрсәләр турында хыяллана бит.* Г. Бәширов.

САЛАМА'НДРА *и. зоол.* Койрыклы җир-су хайваннары семьялыгына керүче, кәлтәгә охшашлы җәнлек.

САЛАМЛЫ *с.* Салам салынган яки тутырылган (капчык һ. б. турында). || Салам катыш булган (мал азыгы, тирес һ. б. турында). *Саламлы кибәк.* □ *Ач кеше — пешмәгән дими, хәтта саламлы, чүпле дими, ни бирсәләр, шуны ашый бирә.* Г. Камал. || Саламы күп булган, саламга уңган (ашлык турында).

САЛАМЧЫ *и.* Ашлык сукканда салам селкү, саламны ташу, өю кебек эшләрдә эшләүче. [*Комбайнчы*] *штурвалны әйләндерә, --- шул ук вакытта я трактортчыга, я саламчы кызларга берәр боерык биреп ала.* Г. Гобәй. *Саламчылар салам чөйделәр.* Ш. Маннур.

САЛАТ I *и.* Сыра кайнату һ. б. ш. максат өчен үрдереп тартылган ашлык оны. *Арпа саласы. Арыш саласы. Салатка үрдерү.* □ *Әнә салат ясар өчен арыш шыттыра торган барак.* К. Әмири.

САЛАТ II *и.* 1. Яфрагы чи килеш ашамлык итеп файдаланыла торган яшелчә үсемлеге.

2. Яшелчәдән генә яки аның янына ит һ. б. нәрсәләр турап, берәр тәмләткеч салып хәзерләгән салкын азык.

САЛДЫРУ I *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* салу I (1—4, 6—29, 31—38, 40—52, 55—60 мәгъ.).

2. *күч. сөйл.* Эре-эре атлау турында. *Пар ат матур гына салдырып китте.* Ш. Әхмәдиев.

САЛДЫРУ II *ф. Йөкл. юн. к.* салу II (1 мәгъ.). || Берәүнең өскә-башка яки кул-аякка кигән, таккан, бәйләгән һ. б. ш. нәрсәсен: чишеп, ычкындырып яки бүтәнчә кире алу. *Баланың киемен салдыру. Авыру кешенең аягын салдыру.* || Хайваннын йөгән, тышау, камыт кебек нәрсәсен: ычкындыру, кире алу. *Атның камытын салдырып алып кую.*

САЛКЫН *с.* 1. Чагыштырмача түбән температуралы. *Салкын кыш. Салкын чишмә. Салкын климат. Салкын җил. Салкын яңгыр.* □ *Бүлмәгез салкын икән, ягып җибәрергә кирәк.* А. Шамов.

2. Кайнарлыгы яки җылылыгы беткән, суынган (аш-су турында). *Әбәтне салкын коймак белән үткәрү. Җиләк җыйганда салкын бәрәңге белән тамак ялгау.* □ *Мәҗлесләрдә искә төшерербез Салкын ашны, салкын идәнне.* Ә. Ерикәй.

3. Җылытмый-кайнарламый гына әзерләнә яки шул рәвештә табынга куела торган (ашамлык турында). *Җәй көне төшкә салкын ашамлык кына әзерләү.* □ [*Чирләп ятучы Төхфәт:*] *Газизә, чәй кирәкмәс, --- чәй эссе ул, салкын әйбер кирәк, алма менә ярый.* Ш. Камал.

4. *күч.* Дәртсез, хиссез; артык җитди. *Ниндидер бер җансыз җитдилек белән катып калган йөзе.*

--- ялкау караган күзләре аның [хурлыкка калган Мостафинның] ничек тә салкын, тыныч булырга тырышуын күрсәтәләр иде. Ә. Еники. || Кырыс холыклы, ягымсыз, артык рәсми мөгамәләле. *[Ипташләре — Зыяга:] Атаң карт сиңа ни өчен бик салкын?* Г. Ибраһимов. *Профессор Дормидонтов --- юридик фәннәрнең рәсми вәкиле, Загоскин шикелле либерал түгел, коры, салкын бер кеше.* Г. Әпсәләмов. || Кырыс, ягымсыз; артык рәсми (мөгамәлә, караш һ. б. ш. турында). *Салкын мөгамәлә. Салкын йөз. Салкын елмаю.* □ *Элекке генераллар алтын ялтыравыгы белән күзне камаштыра, таштан койган салкын чырае, ата күркәдәй кабарынган кыяфәте белән тыныңны куыра иде.* Г. Бәширов.

5. Эшкә мөнәсәбәт, караш һ. б. ш. турында: гамьсез, җавапсыз. *Эшкә булган салкын карашны бетерү.*

6. Җылылык чыгармый яки җылылык чыганагы була алмый яисә җылылыгы сизелми торган (төрле җисемнәр, нурлар турында). *Салкын планета. Салкын нурланыш.* □ *Болыт араларында салкын йолдызлар җемелди.* И. Гази.

7. *махс.* Кыздырмыйча яки түбән температурада эшләнә торган (эшкәртү һ. б. ш. турында). *Сәгатьнең вак кына детальләрен эшләүдә дә бик зур машиналарның катнашы бар. Салкын штамповка бүлегенең бер почмагында идән белән түшәм арасын тутырган зур пресс --- бер үк төрле деталь эшләп чыгара.* М. Максуд.

8. *и. мәгъ.* Салкынлык (1 мәгъ.); түбән температура, салкын һава. *Кышкы салкын. Иртәнге салкын. Боз салкыны.* □ *Кыш көне кар белән ышкыну --- кешене салкынга күнектерә.* Т. Гыйззәт. *Быел көчле салкыннар булганы юк әле.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Салкын алдыру (тидерү)** — салкын тәэсиреннән чирләү. *[Солдатларның] кайберләре мунча чыккан көйгә бозлы су эчеп, шунда ук салкын алдырдылар.* М. Гали. **Салкын алу** — 1) *к.* салкын алдыру.— *Ул бичаракай ничек өшеп, катып бетмәгән соң? Шунда салкын алса?* Ф. Әмирхан. || Бик туңу. *Салкын алдым, калтырыйм.* Ш. Бабич; 2) суыну (бүлмә, әйберләр турында). **Салкын кан белән** — кичерешләргә, хисләргә бирелмичә, зур сабырлык һәм аек акыл белән. *Нәгыйм бер дә каушамыйча салкын кан белән генә җавап бирде.* Ш. Камал. **Салкын канлы** — хисләргә, кичерешләргә бирелмәүчән; аек фикерле һәм сабыр. *Адәм, салкын канлы булырга тырыш.* Г. Коләхметов. **Салкын корал** — кул сугышы өчен булган, кылыч, кинжал, пычак, сөнге, штык кебек чабу-чәнчү коралы. *[Командир:] Ахыр чиктә генә атарга. Салкын корал белән генә эш итегез.* Г. Гобәй. **Салкын сугыш** — сугыш хәзерлүнең бер алымы: әре капиталистик илләрдәге мәгълүм даирәләрнең СССРга һәм халык демократиясе илләренә карата дошманлык белән сугарылган агрессив политикасы. *Хәрби блоклар салкын сугыш чорында оештырылдылар.* Соц. Тат.

САЛКЫНАЙТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* салкынаю.

2. Салкынаю (көн, һава турында). *Кичкә таба көн салкынайту.* || *з-сыз.* Көннең салкынаюы турында. *Әле кичә генә түбәләрдән тамчылар тама иде. Әменә хәзер кай арададыр салкынайтып та җибәргән.* М. Шабай.

САЛКЫНАЮ *ф.* **1.** Салкынга әйләнү, температура түбәнәю. *Каеннарның яфраклары саргая башлады, һава шактый сизелерлек салкынайды.* Г. Әпсәләмов.

2. *күч.* Артык рәсми мөгамәләле, кырыс кешегә әйләнү. *Ни үз күреп йөргән Сания кинәт кенә Маратка салкынаеп китте.* Г. Гобәй. *Егет үзе моны әлбәттә сизә һәм атасының, салкынаймыйча торып та, салкынайган шикелле булып күренүе өчен дә газаплана иде.* И. Туктар. || Берәр нәрсәгә игътибарны киметү, аннан бизә, кызыксынмый башлау. *Элегрәк ул комитетның эшләре белән ни хәтле дәртләнеп янган булса, хәзер шул үк темп белән аңа салкынаюын сизә иде.* К. Тинчурин.— *Белемгә карашың көннән-көн салкыная.* Ш. Әхмәдиев. || Ягымлылыгы, эчкерсезлеге кимү яки бетү (мөнәсәбәт, мөгамәлә һ. б. ш. турында). *Минем аңа [муллага] бәйләнүләрем ике араны боза башлады. Барган саен ара салкынайды.* М. Гафури.

САЛКЫНЛАНУ *ф. к.* салкынаю. *Иртә белән күлдә су салкынлану. Өй салкынлану. Кайбер нәрсәгә кызыксынуың кимеп, аңа салкынлану. Эшлексез кешегә мөнәсәбәтең салкынлану.* □ *Көз башы; төннәр салкынлана башлаган иде.* Ш. Усманов.

САЛКЫНЛЫК *и.* **1.** Салкын булу хәле, түбән температура. *Яратам шушы кичке җәйге һаваның салкынлыгын.* Ф. Әмирхан. *Көннең чатлама салкынлыгы аны бик борчый иде.* А. Расих. *Һавага таң алдындагы тәмле салкынлык төшкән иде.* Г. Тукай.

2. *күч.* Дәртсезлек, хискә бирелмәүчәнлек. || Кызыксынмаучанлык, гамьсезлек. *Бар нәрсәгә дә ниндидер бер салкынлык көчәйде аңарда.* Г. Минский. || Ошатмау-яратмауга нигезләнгән мөнәсәбәтне чагылдыра торган хис. *Таңда солдатка киткән угылына [Җәләлнең] бу дәрәҗәдә салкынлыгы — аңа бер сүз әйтмәве, аның китәчәген телгә дә алмавы кунакларның барын гажәпләндергән иде.* Г. Ибраһимов. *Рәүф белән әнкәсе арасында тугән салкынлык, вакыт үткән саен, көчәя, тирәнәя барды.* Г. Иделле.

САЛКЫНСУ *с. диал. к.* салкынча. *[Музыка] аваз-лары кичке салкынсу һавада салмак кына йөзәләр иде.* И. Гази. *Кичтә һава салкынсурак була.* М. Укмасый.

САЛКЫНЧА *с.* Бераз, җиңелчә салкын. *Салкынча бүлмә. Салкынча күлгә.* □ *Төнге һава салкынча.* Ш. Усманов. *Игеннәрне җиңелчә генә сыйпап салкынча таң җиле исә.* А. Шамов.

САЛКЫНЧАЛАНУ *ф.* Салкынчага әйләнү. *Кичкә таба көн салкынчалану.*

САЛЛАНУ, САЛЛЫЛАНУ *ф.* Саллыга (1 мәгъ.) әйләнү. *Ык суы нинди? Бер карасаң — аның төсе стакандагы су шикелле үтә күренүчән, --- кояш батканда — бакыр кебек кызгылт сары, кичләрен — сафкөмеш. Көзгә таба ул куера, кургаштай саллылана.* М. Шабаев. || Авыраеп, салынып тору. *Ул озын керфекләре һәм салланып төшкән чәче... Я ходай, бу өнме-төшме? Бу түгелме әнкәсе?* Н. Исәнбәт.

САЛЛАУ *ф.* Сал итеп теркәү, беркетү (бүрәнәләрне һ. б.). *Агач саллау.*

САЛЛЫ *с. сөйл.* **1.** Җиңел түгел; чагыштырмача авыр һәм нык. *Саллы гына багаж. Саллы гына таш. Саллы йодрык. Саллы бастырык.* □ *Урман авызындагы түйралыктан --- саллы гына күсәкләр кисеп алдык [арбаны саздан чыгару өчен].* А. Гыйләҗев. *[Эре гәүдәле] Мирсәет абзый саллы зур көрәген ашыкмый гына җиргә батырды.* Г. Ахунов. *Ул башларын игән саллы башакларга үрелде, берничәсен бергә уып карады.* Ә. Маликов.

2. Куәтле, ышанычлы, нык (хәрәкәт һ. б. ш. турында). *Батырның саллы адымы. Саллы селтәнеш.* □ *[Таза көрәшченең] һәр алымы төгәл, хәрәкәтләре саллы.* Соц. Тат. || Төпле, нигезле һәм бик тәэсирле; берәгәйле (сүз, сөйләм турында). *Күңелендә аңа карата әллә ни ачу сакламаса да, [мастерга] саллы гына сүзләр белән җавап кайтарды ул.* Каз утл. — *Куеп җибәр әле кулыңны. Баш механик имзасы белән саллырак булыр [техника сорап язган кәгазь].* Д. Вәлиев. || *сир.* Авторитетлы, төпле, ышанычлы; көчле (кеше турында).

САЛЛЫК *с.* Сал бәйләү-ясауга китә торган яки салга яраклык-җитәрлек. *Саллык бүрәнәләр. Саллык агачны елга буена чыгарып өю.*

САЛМА *и.* Тукмач камырын дүрт почмаклап кисеп яки камырны вак кына кисәкләргә өзгәләп, ашта пешереп алынган ашамлык; чумарның бер төре. || Шундый камыр салып пешерелә торган аш.

◇ **Салма савыты** *гади с.*— авыз турында.— *Фазлый, бирешмә, чәйдәш, салма савытына кундыр!* Т. Гыйззәт.— *Бик ачуны китерсәләр, мәми авызларның салма савытларына да менеп төшәргә бик кыйбат алмабыз.* Г. Камал.

САЛМАГАЮ *ф.* **1.** Салмакка (1 мәгъ.) әйләнү, әкренәю (хәрәкәтнең үзе яки хәрәкәт итүче нәрсә, тавыш һ. б. турында). *Адымнарның салмагаюы. Хәрәкәт салмагаю.* □ *[Көзгә таба] агым салмагая.* М. Шабаев.

2. Басынкыга, сабырга әйләнү (кеше, аның холкы һ. б. турында).

САЛМАК *с.* **1.** Тигез һәм бер көйгә генә, чагыштырмача әкрен дәвам итә торган. *Салмак хәрәкәтле хайван. Салмак адым. Салмак агымлы су. Музыканың салмак агышы. Магнитофонның салмак әйләнеше.* □ *Төнге салмак җилдән Тирбәлә яшел куаклар.* Ф. Кәрим. *Салмак кына гүләп машина бара.* Г. Минский. *Әч пошыргыч салмак тормыш тагын әлеккечә сузыла бирә.* К. Нәҗми. || Йомшак, тигез һәм сузынкы (сөйләм, тавыш һ. б. ш. турында). *Салмак сөйләмле кеше. Салмак көй.* □ *Аның тавышы салмак, йомшак.* Ә. Айдар.

2. Төшеп-салыныбрак тора торган, салынкы. *Салмак болытлар.* □ *Күк йөзе авыр, салмак, караңгы иде.* Г. Ибраһимов.

3. Чагыштырмача бәләкәй, вак булса да, шактый авыр, җиңел түгел. *Борынгырак заманнарда авыл халкы, игеннәр ишелеп уңсын, бөртекләре авыр, салмак булсынга юрап, орлык белән бергә йомырка да чәчә торган булган.* Г. Бәширов. *Унөч яшьтән салмак чүкеч тоткан һәм җир сөргән үсмер дусларга Горур бер көч бирсен безнең сәлам, Куәт бирсен сабан тотарга!* Ш. Маннур.

4. Басынкы, сабыр (кеше, аның холкы һ. б. ш. турында). *Салмак табигатьле булу.* □ *Ректор — сабыр, салмак кеше.* А. Расих.

САЛМАККА *рәв.* Үз көенә, җай гына. *Алтын балдак бармакта, дәлгәндер салмакка.* Җыр.

САЛМАКЛАНУ *ф.* **1.** Салмакка (1 мәгъ.) әйләнү, әкренәю (хәрәкәт яки хәрәкәт итүче нәрсә, тавыш, тормыш һ. б. турында). *Тавыш салмаклану.* □ *Ни эшләп дусларның адымнары салмакланды? Тиз генә узып китәселәре килмиме әллә?* Г. Минский. *[Фәсхи] сизелерлек чүгә төшкән, хәрәкәтләре салмакланган, битенә кара тут йөгергән.* Ф. Хөсни.

2. Салынып, асылынган сыман тора башлау; салынкылану (болыт, тамчы һ. б. турында). *Каяндыр тау артыннан кечкенә генә болыт кисәге күренә. Ул үсә, зурая. Аның янына икенчеләре килеп кушыла. Болыт карала, салмаклана.* А. Шамов.

3. Басынкыга, сабырга әйләнү (кеше яки аның холкы турында).

САЛМАКЛЫК *и.* Салмак булу үзлеге, салмак нәрсәгә яки кешегә хас сыйфатлар. *Хәрәкәтнең яки сөйләмнең салмаклыгы. Көннең салмаклыгы.* □ *Яңалык, тизлек-темп яшь-җилкенчәккә хас, өлкәннәр исә консерватив, алар тынычлыкны, салмаклыкны ярата төшәләр.* А. Тимергалин.

САЛМАЛАНУ *ф. гади с.* Ямьсез булып салыну яки җыерылу (авыз-ирен турында).

САЛМЫШ *с.* Бераз эчкән, исерә төшкән.— *Салмыш чакта кыяфәте гел менә шушылай була аның.* В. Нуруллин.

САЛОЛ *и. махс.* Эчәге һәм сидек юлы авыркан да кулланыла торган дару; әчкелтем ак порошок.

САЛОН *и.* **1.** Пароходта, поездда, кунак өендә һ. б. ш. җирдә: гомуми зал, җәмәгать бүлмәсе. *Кораб салоны.* □ *Театрда халык бик күп, салоннан башка бар урын да тулы иде.* Г. Камал. *Самолёт эче бик иркен, ул өч салоннан тора.* Ә. Маликов.

2. Төрле күргәзмәләр оештырыла торган махсус бүлмә яки бина. *Художниклар салоны. Мода салоны.*

САЛПАЮ *ф.* **1.** Салпы (1 мәгъ.) рәвешкә керү; салыну, салынкылану. *Кошның канаты салпаю. Картайгач иңнәр салпаю. Аргач гәүдә салпаю. Дебаркадерны тарттырып куйган чылбыр салпаю.*

2. Ару, хәлсезләнү һ. б. ш. сәбәпле салмак хәлгә килү, басынкылану (хәрәкәт һ. б. ш. турында). *Адымнар салпаю.*

САЛПЫ *с.* **1.** Салынкы (1 мәгъ.), салынып төшеп тора торган. *Шиңә башлаган үләннең салпы яфраклары.* □ *Өй буенда йомарланып йокымсырап яткан салпы колаклы сары эт --- иренеп кенә башын калкытты.* Г. Бәширов.

2. Арганлык, хәлсезлекне сиздереп торган, басынкы (хәрәкәт һ. б. ш. турында). *Салпы хәрәкәт.* □ *Алиш талчыгып эштән кайтучының салпы адымнары белән ашыкмый гына эчкә таба керә.* Ш. Маннур.

3. *күч.* Төшенке (күңел, кәеф турында). *Аның ни өчендер күңеле салпы иде.* Ш. Маннур.

◇ **Салпы якка салам кыстыру** — берәүне үз алдында мактаган булып үсендерү. *Исән-сау ерып чыгып булса, кызның менә дигәненә тиенәсең инде син, малай, дип, әледән-әле минем салпы якка салам кыстыра Госман.* Ф. Хөсни.

САЛПЫЛАНУ *ф. к.* салпаю. *Телеграф чыбыгы салпылану.*

САЛПЫЛЫК *и.* Салпы булу сыйфаты яки хәле. *Волейбол челтәренең салпылыгы. Хәрәкәтнең салпылыгы.* □ *Басынкылык, кәеф салпылыгы әкренләп югала бара, күңелдә җиңеллек уяна.* Ш. Маннур.

САЛПЫРАЮ *ф. к.* сәлперәю. *Менә әткәң әле дә исән, Гөлсем, Тик бөкрәйгән аның җилкәсе, Кырауларда шиңгән чәчәк кебек Салпырайган ике иңсәсе.* Н. Баян.

САЛУ I *ф.* **1.** Берәр нәрсәнең эченә төшереп, куеп, сыек булса агызып, коеп һ. б. ш. рәвештә урнаштыру. *Вак акчаны кесәгә салу. Китапны сумкага салу. Самоварга күмер салу. Кисмәккә су салу. Гармуньны тартмасына салып кую.* □ *Хәят карточканы китап эченә салды.* Ф. Әмирхан. *Савытларыбыз тулып җитмәгәнгә, --- җиләк өстенә әзрәк шомырт җыеп салдык.* М. Гали.

2. Гадәттә озынча нәрсәләрне: яткырып, аударып, сузып яки таратып кую, урнаштыру. *Хәким белән Талип яшел чирәмгә утырдылар, таякларын яннарына сузып салдылар.* Ә. Еники. *Ул ишкәкләрне җилкәсенә күтәреп салды да атлап-йөгереп яңадан яр астына төшеп китте.* М. Хәсәнов. *Ул арыш саламын киң кочагында ашыкмый гына [мич алдына] кертеп сала да, шуны урап, бик акрын гына ягарга тотына.* Г. Ибраһимов. || Берәр нәрсәнең өстенә куеп, орындырып-тидереп тору (кулны, башны, аякны һ. б.). *Кулны артка салып бару. Беләкнә өстәлгә салу. Башны мендәргә салу. Этнең башын аягына салып ятуы.* □ *Гаяз яныма килеп иңемә кулын салды.* М. Әмир. *Талип теләр-теләмәс кенә --- ишеккә таба атлады. Шунда җиткәч ул кулын тоткага салды, туктады, башын игән килеш идәнгә карап торды.* Каз. утл. *Ат мескенләнеп, ялынып, башын аның иңбашына салды.* А. Шамов. || Ике якка салындырып, аркылы кую. *Шәлне, плащны беләккә салып йөрү.* □ *[Бакый] чыбыркыны җилкәсенә салып ташка утыра.* М. Фәйзи.

Алар, сөлгеләрен иңнәренә салып, Идел буена киттеләр. Г. Бәширов.

3. Җәеп-таратып яки сузып урнаштыру, кую; түшәү. *Баш астына мендәр салу. Ияр астына киез салу. Алга тастымал салу. Ерганак аркылы такта салу. Дебаркадердан пароходка трап салу. Олтырак салу. Сарайны мүк салып бураю. Мамык салып сырган бишмәт.* || Вакытлыча яки тиз генә җәю, әзерләү (йокы урынын).— *Шунда сәкегә, стена кырыена гына урын салып яткырыйк бу баланы.* М. Гали.

4. Төяү (йөкне). *Товарны машинага салып кайту.* □ *Салам төяүчеләр безгә юри күп салалар иде.* Г. Ибраһимов.— *Менә миңа карагыз! — дип мактана паровоз,— Туксан тугыз вагоным бар, Меңәр пот йөк салабыз.* Б. Рәхмәт. || Күтәртү яки күтәрү (йөк һ. б. ш. нәрсәне). *Таулы якларда йөкне ишәк аркасына салып ташу. Авыр капларны иңгә салып алып керү.* □ *Ул капчыкны яңадан җилкәсенә салды.* М. Җәлил. *Яраланган килеш ул мине Ике чакрым, салып сыртына, Алып килгән санбат йортына.* Г. Афзал. *Шәм кебек төз каен агачлары — ярдырыргадыр инде. Ул аларны --- ян башына салып [ташый].* Каз. утл.

5. Гәүдә авырлыгын: берәр әгъзага, гәүдәнең берәр өлешенә яки терәк булырдай нәрсәгә йөкләү-төшерү, күчерү, туры китерү. *Ул гәүдәсенең авырлыгын сул аягына салган.* М. Әмир. *Чаңгыга баскач, хәрәкәт җиңеләйгәндәй булды. --- Таякларга авырлыкны саласың да чаңгыларны гына шудырасың.* Ә. Маликов.

6. Кимичә, өскә, иңгә генә ябу (өс киемен). *Бишмәтне аркага гына салып капка төбендә тору. Плащны иңгә генә салу.* □ *— Туңасың бит. Һич булмаса, иңбашыңа җылы кофтаңны салып чыгар идең.* С. Шәкүров. [*Больницадагы авыруның*] *хәлен белергә Зөлхәбирә килде. --- Күлмәк өстеннән ак халат салып кергән иде.* Г. Ахунов. || Бәйләмичә генә ябыну, бөркәнү яки иңгә-аркага ябу (яулыкны, шәлне һ. б.). *Хатын-кызларның яулык өстеннән шәл салуы.*

7. Яткыру. *Баланы бәләкәй арбага салып йоклату. Яңа туган бозауны салам өстенә салу.* □ *Табынын җыеп, Хәлимне йокларга салгач, Фатыйма каба төбенә утырып җеп эрләргә тотынды.* И. Гази. *Салды да кабык бишеккә Үстерде безне авыл.* Г. Латыйп.

8. *күч. сөйл.* Көрәштә: егу, җиңү. *Аркага салу.* □ [*Егучы көрәшчегә теләктәш тамашачылар:*] *Менә шулай! Ай-яй һәйбәт салдың!* Ф. Әсгать. *Икенче көрәшчене Нәфүш бер күтәрүдә салды.* Г. Ахунов.

9. Дәвалау, укыту-тәрбияләү һ. б. ш. максат белән, тиешле вакытына берәр җиргә урнаштыру, кертү, бирү. *Зинданга салу. Яралыларны госпитальгә салу.* □ *Аны Каргалының биш йөз шәкертле кара, кадим, фанатик мәдрәсәсенә салалар.* Г. Ибраһимов. [*Аклар*] *аның атасын асып үтергәннәр, ә үзен бик каты кыйнап төрмәгә салганнар.* А. Шамов. || Дәвалау-дарулау, савыктыру-төзәтү максаты белән берәр режимга кую, күчерү, дучар итү. *Сынган аякны гипска салу.*

10. Ию, бөгү, салындыру, авыштыру (башны һ. б.). *Көннең эсселегеннән ялыккан ат, башын салып, ялкау гына дырык-дырык атлап килә.* М. Гали. *Башын алга салыбрак, ашыкмыйча гына урамнан узганда да авылга --- үзенә күрә моңсу бер ямь биреп уза иде [Рәхмәтулла агай].* М. Рафиков. || Төшерү, салындыру, аска юнәлтү (борынны һ. б.). *Борын салып утыру.* || Салындыру (керфекне, канатны һ. б. ш.). *Казның канатын салып торуы.* □ *Газизә озын керфекләрен түбән салып кайгырып тора.* Ш. Камал. *Уреп салган кара толымы Төшеп тора нечкә биленә.* Ә. Юныс.

11. Атлау, басу (аякны). *Ул бик алга да узмыйча, бик үк артка да калмыйча, аякларын җай гына салып барганлыктан, көчен саклый алган иде.* Г. Бәширов. *Юырткында аякны әллә кайдан китереп сала [бу айгыр].* М. Гали. || *сөйл.* Ясау (гадәттә эре адымны). *Адымны эре салып бару.* || Ясау, йөртү (колачны, киң колач белән йөзгәндә — кулны). *Колачны киң салып йөзү.* || Ишү (ишкәкне). *Арслан ишкәкләрне шундый оста сала белә икән, хәтта алардан су тамганы да ишетелми иде.* Ш. Маннур.

12. Сыек яки бөртекле, кисәкле нәрсәне: аралаштыру-катнаштыру өчен икенче бер шундый нәрсәгә кушу. *Сөткә оеткы салу. Камырга сода, чүпрә салу.* □ *Чәй эчеп утырган вакытта теге кеше Тарабаровның стаканына йоклата торган дару салып эчерткән.* Г. Камал. || Ашамлык, тәмләткеч кебек нәрсәләрне: өстәп, кушып катнаштыру. *Чәйгә шикәр салу. Буткага май салу. Бәлешкә йөзем җимеше салып пешерү. Токмачны вакытында салу.* □ [*Килене:*] *Мин ашка бәрәңгене салдым инде.* А. Әхмәт.

13. Чирне кисәтү, дәвалау өчен яки бүтән максат белән тәнгә кертү, сендерү, йоктыру яисә тамызу (дару, агу һ. б. ш. нәрсәләрне). *Күзгә дару салу. Канын күп югалткан яралыга кан салу. Чәчәк салу.* □ [*Патша армиясенә китмәс өчен башкалар*] *аякүл бозалар, күзгә, колакка агу салалар. Без моңа якын бармадык.* Г. Ибраһимов. || Уколны: ясау, куллану. *Грипп уколы салу. Пенициллин уколы салу.* || Банка, сөлек кебек нәрсәне: суыртып дәвалау өчен, тәнгә махсус кую. *Аркага банка салу. Сөлек салучы карчык.* □ [*Мәһитап:*] *Күрше Сәйфуллага сөлек салырга керәм.* Т. Гыйззәт.

14. Җәрәхәтне, имгәнгән җирне һ. б. ш. саклау өчен, бәй, гипс катламы кебек нәрсәләрне: җайлап беркетү, кую, бәйләү. *Сынган кулга гипс яки шин салу. Беләкнең пешкән җиренә бәй салу.*

15. Тегеп, ябыштырып яки бүтәнчә беркетеп кую (ямауны, олтанны һ. б. ш.). *Чыбылдыкка ямау салу. Итеккә олтан салу. Күлмәккә кесә салу. Астар салу.* □ [*Галләметдин*] *калын гына аслар салган зур киез итекләренә сырышкан карны каккалап алды.* Ш. Камал.

16. Ягу-сөртү, сылау, буяу һ. б. ш. йоктыру (иннек-кершән, буяу кебек нәрсәләрне). *Элекке хатын-кызларның тешләренә кара салуы. Буяуны артык калын салу.* □ [*Фәрхиназ*] *әйбәтләп киенде, иннек-кершән салып бизәнде.* Т. Гыйззәт. *Күз төпләре капчыкланып төшкән булса да, [карчык] күзенә сөрмә тарткан, битенә пудра салган.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

17. Тамга, билге, бизәк-сыр кебек нәрсәне: кую, ясау, төшерү (язып-сызып, уеп-чокып һ. б. ш.). *Бизәк салу.* □ *Ике карт тамга салды, староста мөһер басты да кәгазьне әткәйгә бирде.* Г. Ибраһимов. [*Әбүгалисина*] *учак каршында утыра һәм китабына аратирә ниндидер билгеләр сала.* Н. Исәнбәт.

18. Резолюция, виза һ. б. ш. нәрсәне: язу, бирү. *Имза салу. Гаризага резолюция салу.* □ [*Командир*] *минем рапортка, --- каравыл взводына җибәргә дип, виза салды.* Ә. Еники. || Кайбер абстракт исемнәрдән соң: шуңа дучар итүне белдерә. *Милеккә яки банктагы счетка арест салу. Берәр кәрарга вакытлыча вето салу. Табу салу.*

19. Башлау, ясау, яру (юлны, сукмакны һ. б. ш.). *Гөрләвекнең кар астыннан юл салуы.* □ *Эти беренче буразнаны салды да, каядыр барасы булыпмы, кайтып китте.* Ш. Маннур. || Ясау, калдыру, барлыкка китерү (эзне, җәрәхәтне һ. б. ш.). *Кемдер инде бу юлдан әз салып үткән. Бикмуллинның Бөгелмәгә киткән машина эзе булса кирәк.* Каз. утл.— *Кая ул онытылу, бәпкәм, йөрәккә җәрәхәт салган ул еллар онытыламы соң...* А. Әхмәт. *Туган илнең һәрбер үзгәреше Күңелләргә сала үз эзен.* Р. Харисов.

20. Кабызып-яндырып җибәрү, төртү (утны).— *Кызым, самоварга ут кына салып җибәр әле.* Г. Камал.

Утын, су ташып, мунча миченә ут салдык. Э. Касыймов.

21. Корткычлардан сакланy-саклау максаты белән һавага тарату, тирә-юньгә бөркү, бүлмәгә сендерү (төтенне, даруны һ. б. ш.). *Умарта караганда төтен салу. Подвалга ыс салу.* □ *— Алмаларга төтен саласым бар, диде Локман.* Х. Сарьян. || Суны: эссесе, пары чыксын өчен мунча ташына сибү. *Мәймунә түти килеп, аларга [кунакларга] мунчаның кайдалыгын күрсәтте һәм юынырга, ташка салырга дигән суларның, мунчала-сабыннарның кайда торганлыгын әйтте.* М. Гали. || Эссене, парны: ташка су сибеп, чыгару, булдыру, ясау. *Эссе сала-сала чабыну.* □ *Ана карчык, аңа суык тигән дип уйлап, мунча якты, күп итеп пар салып каен себеркесе белән Рәүфәне бик каты чабындырды.* А. Шамов.

22. Савытка бүлеп алга кую, бирү (аш-суны). *Рәхим мәктәптән бик күңелсезләнеп кайтты. Әнисе аш салып бирде. Малайның ашыйсы килми иде.* Г. Мөхәммәтшин.— *Ярый, кузгалыйк алайса, диде ул, салган чәен эчеп бетереп.* М. Гали. || Бирү, ташлау, сибү (малга, кош-кортка азыкны). *Атка печән салу. Тавык-чебешкә җим салу. Малларның алдына салу.* || Марля кебек юка әйбернең эченә сыеграк ашамлык салып ясаган имезлекне: әзерләп кую яки бирү (имчәк баласына). *Әнисе әштә чакта балага имезлек салып тору.* || Бит-кул юучыга суны: агызып тору.— *Бар, шәкерт абыеңның кулларына су сал, диде әнисе кызына.* Ә. Фәйзи.

23. Туй бүләге кебек нәрсәне: котлап табынга кую яки бирү. *Туй котлап бүләк салу.* □ *— Мәһәр котлап ни салырмын икән?* М. Фәйзи. || *иск.* Мәһәр кебек нәрсәне: бирү. *Саткай, --- Хәйрулла картны башкодага җибәреп, [кызның атасы] ни сораса — шуны сал, күпме сораса да — сал [мәһәрне], тик Майбәдәрне ычкындырма, дигән.* Г. Ибраһимов.

24. Отышлы өстәл уеннары уйнаганда акчаны һ. б. ш. отышка билгеләнгән нәрсәне: уенга кую. *Лотоны икешәр тиен салып уйнау.* □ *[Кәрт уйнаганда] кайбер солдатлар күзенә берәр тиен генә салып уйнасалар да, сәгать эчендә җитмеш биш тиенне [барлык жалованьене] калдырып, читкә китеп утырдылар.* М. Гали.

25. Жирәбә кебек нәрсәләрне: чират билгеләү, өлеш алу һ. б. ш. өчен файдалану. *Җир бүлгәндә жирәбә салу. Чиратны жирәбә салып билгеләү.* □ *[Ленинны күмүдә катнашу өчен] крестьяннардан делегация җибәрергә дигән уй булды. Барырга теләүчеләр бик күп. --- Шуннан соң шобага салдылар... Кулым калтырый. Чыкмастыр кебек. Бүреккә тыгылам; ачсам — „Ленин" дип язылган.* К. Нәҗми. || Күрәзәлек итү максаты белән төрлечә таратып, аралаштырып һ. б. ш. рәвешле тезү, урнаштыру (багу әсбапларын). *Фал салу. Борчак салу.* □ *[Качкинский] өйдән өйгә кереп кәрт сала, закон сата, солдаткалардан кашыклап май җыеп, әчегән сөт эчеп йөри.* Н. Исәнбәт. *[Әхмәт:] Байларга комалак салдыңмы? [Карт:] Әйе, бай кызының бәхетен карадым.* М. Фәйзи. || Берәр нәрсәне яки кешене шобага я багу предметы итү, жирәбәгә язып һ. б. ш. рәвештә объект итеп алу. *Жирәбәгә салу.* □ *Егет сайлау уенында мине өч кат салганнар. Мин өчесендә дә дсмага чыкканмын.* Г. Ибраһимов.

26. *чыг. килеш. исемнән соң.* Чамалап карау, алдан билгеләү, бүлеп кую өчен: хисаплау (керем-чыгымны һ. б. ш.). *Центнерын берәр сумнан гына салганда да биш машина ашламага йөз сум кирәк булу.* || *юн. килеш. исемнән соң.* Алдан хисаплап, чамалап: билгеләү, күнелдән бүлеп кую. *[Зәйнәпбану] өстәмә итеп алачак бодаеннан йорттa нилəр җиткерәсен, туйга нилəр әзерлисен исәпли иде: — Мунча миченә салыйм бер өч пот, „үзенә" пальто тектерергә кирәк булыр кимендә биш пот. Аннары килеп, икебезгә киез итек бастырырга тагын ике-өч пот...* Г. Бәширов. || Счёт белән исәпләү-санау турында. *— Мин кибеттә чут салып кына утырам.* Ә. Фәйзи.

27. Юнәлеш килешендәге үлчәм белдерә торган сүздән соң: шул система берәмлегенә күчерү; күчереп исәпләү. *Центнерлы йөкне потка салып чамалау.* □ *Кошлар очып житмәс ерак Себер ята иде арада. Чакрымнарга салсаң — ерак идегез, Йөрәкләргә якын эшче калалар.* Д. Фәтхи. *[Сугыштан кулсыз кайткан МТС директоры:] Бүгенге көндә ат көченә салсаң, шушы сыңар кулымда ничә мең ат көче бар!.. Я, ал әлекке иң зур алпавытны. --- Аның ат куәтен кара... Минем янда кем ул?!* Н. Исәнбәт.

28. Киләчәккә дип махсус әзерләп (сакларга) кую яки саклыкка дип аерып калдыру (чәчү орлыгын, азык-төлекне һ. б. ш.). *Орлыкка бодай салу. Силос салу. Базга кар салу. Чокырга бәрәңге салу.* || Берәр саклау урынына жыю, туплау (ашлыкны һ. б. ш.). *Глубинкага ашлык салу.*

29. Сакларга тапшырып тору (кассага һ. б. ш. махсус жиргә). *Акчаны, облигацияләрне саклык кассасына салу.* □ *— Акчаны банкка салыгыз.* Ш. Мөхәммәдев. || *махс.* Бурычка акча яки вакытлыча файдаланырга ни дә булса алу өчен берәр әйбереңне: биреп калдырып, куеп тору. *Сәгатьне ломбардка салу.* □ *— Кибетчегә сигез сумга салып кына торам [самоварны[. Ашлык саткач кире алырбыз, хәзер менә ясак түләүне бик кысып теңкәгә тияләр.* Г. Ибраһимов. *Актык көмеш тәңкәсен Заклад салды хатыныңдәйтеп бирәм дөресен, Калса калсын хәтерең.* Н. Думави.

30. Күнелгә-хәтергә алу, кабул итү (сүзне, киңәшне, кисәтүне һ. б. ш.).— *Бу сүзләрне онытма, күңеленә сал.* М. Гафури.— *Сүзләреңне күңелемә бик тирән салып куйдым.* Х. Вахит.

31. Юк итү, яраксызга әйләндерү максаты белән яки кадерсезләп берәр жиргә ташлау. *Утка салу. Жиргә салып таптау.* □ *Менә бер көн моны [алмазны] бер вәхши алган, Нигә соң бу? — дигән дә суга салган.* М. Гафури.

32. Бирү, сарыф итү, чыгару (көч, сәләт, тырышлык, акчаны һ. б. ш.). *Бу рәсемгә художник бөтен ижат көчен, бөтен дәртен, сәләтен салган булса кирәк.* А. Шамов. *Бикмуш бабайның бөтен көчен салып ишүенә дә карамастан, дулкыннар көймәне түбән таба кудылар.* Г. Гобәй. || Капиталны: хуҗалыкка, төзелешкә бүлеп бирү, жибәрү. *Капиталны хуҗалык тармакларына пропорциональ салу.*

33. Юнәлтү, төбәү (уйны, игътибарны һ. б. ш.). *Ниятне бер нәрсәгә генә салу.* □ *Д яратсаң — унбиш ел түз, ятка күңел салма син!* Ш. Маннур. *Ефәк күлмәккә генә зиһен салмыйк, Аннан кирәгрәген карыйк.* Ш. Мөхәммәдев.

34. Берәр төрле мәгънә, эчтәлек бирү (сүзгә, сөйләмгә, жырга һ. б. ш.). *Сүзгә яңа мәгънә салып куллану. Дсәргә заман рухын салу. Сөйләмгә ироник төсмер салу.* □ *Муса шундый итеп жырлаган ки, --- бар моңын, бар сагышын шушы жырга салган!* Р. Батуллин.

35. Ишеттерү, бирү (тавышны, авазны, өндәүне һ. б. ш.). *[Сибай — Шәмсетдингә:] Я, ишетим тавышыңны, бер аваз сал, жый халыкны, патша төшерәбез!* Г. Бәширов. *Көчле күк күкрәве, юлбарыстай, Киң сахрага тавыш сала.* Һ. Такташ. || Тарату, ишеттерү-ирештерү (хәбәрне, сүзне, чакыруны һ. б. ш.). *Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган. Шул турыда төрле якка хәбәр дә салган.* А. Алиш. || Ясау (ымны һ. б. ш.). *Мәүлиха апа да таптанып*

минем янда тора; күрәм, Кәримәнең дә миңа нидер әйтәсе килә, --- керфекләрен уйнатып миңа күз кыса, ым сала. А. Гыйләҗев. || Ымлыклардан һәм бүтән кайбер сүзләрдән соң: шуны нык ишеттерү, шуны әйтеп кычкыру. *Ай-һай салу. Сөрән салу. Яр салу. Разбой салу.* □ *Чүмәлә тарттыручы малайлар һай-һу салып атларны куалар.* Ф. Хөсни. [*Баймурат Гыйлемдарга:*] *Бар, мәдрәсә шәкертләрен уят, каравыл салып халык җый. Гыйбрәт күрергә килсеннер.* Т. Гыйззәт.

36. Почта яки багаж белән һ. б. ш. җибәрү. *Хат салу. Телеграмма белән акча салу. Китапны бандероль итеп салу. Юл йөргәндә әйберне багаж белән салу.* □ *— Миңа җавап язып салырга ашыгам.* М. Җәлил. *Дниләренең бәйрәменә алар [читтәге балалары] күп итеп күчтәнәчләр һәм бүләкләр салганнар.* Л. Ихсанова. *Хаты белән бергә яңа төшкән Рәсемен салды үзенең картына.* Һ. Такташ.

37. Берәр төрле рухи-психик халәт яки сыйфат тууга этәргеч бирү, сәбәпче булу; дәрт-рух бирү. *Берәүнең йөрәгенә ялкын салу.* □ *Якупның гади һәм хак сүзләре аларның --- йөрәкләренә кыюлык сала.* И. Гази. [*Ул җырны*] *бер җырлау да күңелгә бетмәс-төкәнмәс көч сала ди.* А. Алиш. *Күңелгә беренче изгат очкыннары салучылар да шулар бит инде — беренче укыган китаплар, беренче караган спектакльләр, фильмнар.* Р. Төхфәтуллин. || Коткы кебек нәрсәләрне: тарату, чыгару, барлыкка китерү. *Шом салу.* □ *Маташмагыз якты көнне караларга, Дошманлык салырга дип араларга.* Г. Камал. *Курку салып дошман йөрәгенә Безнең тавыш белән шаулый җил.* Б. Рәхмәт. *Нәрсәнедер яшереп каласың, Чишкән чакта серләр капчыгын; Күңелгә шик-шөбһә саласың, Сөйләмичә эшнең асылын.* М. Хөсәен. || Күңелсезлекне, бәхетсезлекне: китерү, шуңа сәбәпче булу, шуңа дучар итү. *Җәбер, борчу, зарар салу. Дәһшәт салу.* □ *Яман дус юк урында хафа салыр.* М. Гафури. [*Шүрәле:*] *Моннан соң һичкайчан да кеше затына зыян салмам.* Д. Аппакова. || Җәзаны: бирү, шуңа хөкем итү.— *Ул миңа нинди җәза салыр икән?* М. Фәйзи. || *юн. килеш. сүздән соң.* Фикер, идея, план һ. б. ш. нәрсәне: әйтү, бирү, күңелгә төшерү, хәтергә китерү. *Ул ике фикернең беренчесен колхозның яңа председателе Бикташев салды аның башына.* М. Әмир. *— Ярый әле, минем дә искә салдың.* Г. Минский. || *юн. килеш, сүздән соң.* Берәр төрле рухи халәткә яки хәлгә: дучар итү, шуңа төшерү. *Нужага салу. Шомлы хәбәрнең кешене куркуга салуы. Уйга, шиккә салу. Кайгыга, борчуга салу.* □ *Зәңгәр күл түгел, зәңгәр күз Салды мине сагышка.* Г. Насрый. *Авылның яшь-җилкенчәген аптырауга салып, Мансур Гөлниса өенә күчеп чыкты.* Каз. утл. *Ул үзен үзе харап итә, үзен үзе һәлакәткә сала.* Г. Коләхметов.

38. Налогны, төрле түләүләрне, салым-җыемнарны: түләргә дип билгеләү, шуңа дучар яки мәҗбүр итү. *Налог салу. Түләү салу. Штраф салу.* □ *Авыр ясак салды [хан].* М. Җәлил. [*Аклар*] *суктыруларны туктатканнар, авылга контрибуция салганнар: мең пот иген, егерме баш ат, утыз баш сыер, йөз баш сарык.* И. Гази. || Йөкләү; ясарга, эшләргә-үтәргә дучар яки мәҗбүр итү (чыгымны һ. б. ш.). *Чыгымны аның [мәрхүмнең] семьясы җилкәсенә салмыйча, бергәләп үз өсләренә алырга булдылар [кардәшләре].* С. Әдһәмова.

39. Үз иркенә-ихтыярына, карамагына: кую, калдыру, җибәрү. *Атланган кеше аны [чабып барган атны] хәзер ашыктырмый, үз ихтыярына салган.* Ш. Камал.

40. Тәртипкә, җайга, нормаль хәлгә: китерү, яраштыру. *Эшне, тормышны көйгә салу. Фикерләреңне тәртипкә салу. Системага салу. Халыкара мөнәсәбәтләрне җайга салу.* □ *Идел үзенең киң юлын тузан, төтен чыгармыйча гына, яр кырыйларын дулкын белән ишеп кенә рәткә сала.* К. Нәҗми.

41. Көйгә, рифмага туры китереп җайлаштыру, шуңа яраклаштырып эшләү (җырны, әдәби әсәрне һ. б. ш.). *Шигырьне көйгә салып җырлау. Әсәрне музыкага салу.* □ *Тәнкыйтьчедән мондый әсәрләргә Киресенчә була гел бәя: Чәчмә итеп язсаң — поэзия, Тезмә итсәң — гади хикәя... Ни булса ул, салдым тезмәгә, Ошар әле бәлки сезгә дә.* Н. Арсланов. || Нотага күчереп яки оркестрга яраклаштырып: язу (көйне).— *Хәтерлисеңме, синең беренче көеңне нотага салдык.* Р. Ишморат. [*„Шүрәле“ спектаклендә*] *көйләрне оркестрга салу эшләрен профессор Юдин башкара. Биюләрне Гай Таһиров куя.* Каз. утл.

42. Пешерергә кую (аш-суны). *Аш салып көтү.* □ *— Әйдә, Исәнбай, самоварны ал да, син чәй куярсың, мин аш салам.* Т. Гыйззәт. [*Гөлбикә*] *чәйдән соң казан асып ит салды.* Г. Ибраһимов. || Пешерергә кую яки пешерү (ипине, мич ашларын һ. б. ш.). *Күмәч салу. Мичкә бәрәңге салу.* □ *Мәүлиха түти ипи салырга дип бүген иртәрәк кайткан иде.* Г. Бәширов. *Йөземләп салган дөге бәлеше иде ул!* Ф. Бурнаш. || Ачытырга дип кую (балны һ. б. ш. әчемлекне). *Бәйрәмгә дип сыра салу. Туйга бал салу.*

43. Җебетеп-йомшатып эшкәртү өчен: суга батыру, тиешле вакытка суда калдыру (мунчалалык кабыкны, киндерне һ. б. ш.). *Елга тармагын буып баса салу. Киндер салу.* □ *— Д син беләсеңме, дптелкәрим дус, мунчала сала торган күлне?* Ә Фәйзи.

44. Ашламаны: туфракка кертү, җир ашлау өчен куллану. *Уңышның нигезе туфракны эшкәртүдә һәм вакытында тиешле ашлама салуда.* Каз. утл.

45. Сугарга-тукырга дип хәзерләп станга корып кую (киндерне). *Ак киндер салу. Тула салу. Салган киндерне тизрәк сугып бетерергә ашыгу.* || Сугу, туку. *Бәйрәм алдыннан сөлгелек салып алу.*

46. Аулау-тоту өчен дип махсус кую, кору (ау, капкын, җәтмәне һ. б. ш.). *Куянга бугалак салу. Төнгелеккә инешкә сөкә салып калдыру. Кармакны балыклырак урынга барып салу.* □ *Капкын салып йөрдем бүрегә.* З. Мансур. *Балыкчылар ашыга-ашыга ау салалар.* М. Укмасый. *Көн саен ул елгага үзенең җәтмәсен сала һәм көн саен мул итеп балык тартып чыгара.* Каз. утл.

47. Тышау, богау, йозак кебек нәрсәне: ычкынмаслык, ачылмаслык итеп бәйләп, буып, бикләп яки бүтәнчә беркетеп кую. *Атка тышау салу. Тоткыннарның кул-аягына богау салу. Ишеккә йозак салу.* □ *Солдат итеп алдылар, билгә каеш салдылар.* Җыр. || Элмәк, мунчак кебек нәрсәне: кидерү, әләктерү. *Дарга асылучының муенына элмәк салу.* □ *— Кәҗәнең мөгезенә бауны салдым да җитәкләп өйгә алып кайттым.* Ш. Камал. || Бастырык, эшермә яки киртә кебек нәрсәне: ишекне-капканы бикләү яки юлны ябу өчен аркылы куеп махсус урнаштыру. *Маллар чыгып таралмасын өчен араның керү-чыгу урынына киртә салу.* □ *— Өйалды ишегенең эчтән бастырыгын салып торыгыз.* М. Фәйзи. || Кыршау кебек нәрсәне: махсус кую, беркетеп эшләү, сугу. *Иран сугышына китешли, Петр I кызыксынып Болгарга туктый. --- Ике манараның өсләренә менеп, тирәякны күзәтә, аларны төзегән болгарларның осталыгына хәйран кала; берсенең ярыла башлаганын күреп, тимер кыршау салырга боера.* Каз. утл.

48. Тормоз кебек нәрсәне: тизлекне киметергә яки йөрешне-хәрәкәтне туктатырга кирәк булганда, тәгәрмәч әйләнмәсен өчен куллану. *Таудан йөк белән төшкәндә арбаның арт тәгәрмәченә тормоз салу. Машинаны кинәт туктатканда тормоз салып туктату.*

|| Якорь кебек нәрсәне: йөрешне-хәрәкәтне туктату яки тизлекне киметү өчен куллану. *Көймәдән балык тотканда якорь салу.* □ *Саратауга килеп җитәр алдыннан, өч-дүрт чакрым калганда, [пароходыбыз] якорь салып туктады.* Ф. Әмирхан.

49. Эшкә керешкәндә коралны куллана башлау, шул корал белән эшли башлау турында. *Пычкыны җайлы салу. Пычак салу. Кишәрлектә беренче урак салып кайту.* □ *Кичә Кырлайныкылар шунда барып үз печәнебез дип чалгы салулары була, алпавытның болын каравылчысы килеп чыга да боларны тота.* Ә. Фәйзи.

50. Төзү, кору, җиткерү, эшләү (каралты-корылманы, эре хуҗалык объектларын һ. б. ш.). *Өй, мунча, келәт, сарай, күпер, ферма, гараж, мастерской салу. Яңа шәһәр салу.* □ *Кеше кулы далаларда калалар сала.* А. Алиш. || Кору, эшләү-ясау (ваграк хуҗалык объектларын һ. б. ш.). *Мич салу. Һәйкәл салу.* || Терәү кебек нәрсәне: җайлап урнаштыру, махсус кую. *[Мәршидә Биктимергә:] Абзарның өрлеге сыгылган, эчтән берәр терәү кисәге салырсың.* Т. Гыйззәт.

51. Нигез, фундамент һ. б. ш. төзегәндә бетон, цемент кебек материалны: кою.— *Эшләрнең дә ахыры күренеп килә инде. ГЭСта [электр станциясе төзелешендә] бетон салучы бары өч кенә бригада калды.* Ш. Маннур. || Төзү эшендә кирпеч, таш кебек материалны: тиешенчә беркетеп кую, тезү, өю. *Төрлесе үтте баштан. Маляр булып буяп та карадым, каменщик булып кирпеч тә салдым.* Каз. утл.

52. Печән, көлтә, утын, бүрәнә кебек нәрсәне өеп, кибән, чүмәлә, штабель һ. б. ш. ясау. *Көлтәдән чүмәлә салу. Эскертне биек итеп салу.* □ *Сәйфетдин карт кулына сәнәк тоткан, кибән сала.* Ф. Әсгать. *Хәйдәр, өченче көшелне сала башлаганнан соң, баганага әленгән озын кәгазенә потлар исәбен санап чыгарды.* Г. Бәширов. || Печән, көлтә, утын, бүрәнә кебек нәрсәне кибәнгә, чүмәләгә, эскерткә, штабельгә һ. б. ш. өемгә өю. *Тиресне өемгә салу. Көлтәләрне чүмәләгә салу.* □ *Колхозчылар җыеп алып аны [саламны] Эскерт итеп сала баралар.* М. Гаяз. *Эти белән икәүләп ике зур арба арыш төяп, хәзрәтнең ындырына алып, кибәнгә салып, дога кылдырып кайта торган идек.* М. Гафури.— *Парга керешкәнче, [урманны] ничек тә тизрәк кисеп бетерергә и бер очтан сала да башларга.* Ф. Хөсни.

53. Карны, ләмне һ. б. ш. нәрсәне: өю, берәр җиргә китереп түшәү, катлам итеп калдыру, җыебрак яткыру (җил, буран, агым турында). *Кичәге буран кар салганлыктан юл авыр булса да, атын юыртгырып алып китте ул.* В. Нуруллин. || *з-сыз.* Кар, ләм кебек нәрсәнең җил, агым тәэсире белән берәр урынга җыелыбрак түшәлүе, катлам булып ятуы турында. *Агачлар кирәгеннән артык куе утыртылган. Шул сәбәпле полоса буйларына калын итеп кар сала.* Каз. утл. *Юлга бик нык салган, атлар әкрен атлыйлар, яшь кар өстеннән чана табаннары үкереп шаулап бара.* Ф. Хөсни. *Буран һаман басылмаган иде әле. Тик Дәмин йөзгә бәргән карны да, аяк астына салган көртне дә сизмәде.* Б. Камалов.

54. *күч. сөйл. гадәттә з-сыз.* Бик ишле, көчле яву (яңгыр, кар турында).— *Бер ява башлагач явар инде. — Яумый хәле юк.— Бер елны да башта шулай булган иде. Шуннан соң сала башлады — тотын гына!* Ш. Камал.

55. *күч. сөйл.* Сугу, бәрү. *Салып егу.* □ *Басу капкасын чыгу белән чыбыркыны сызгыртып җирән айгырның сыртына берне салган идем, айгырым дөлделдәй оча башлады.* Ә. Айдар. *[Алпавыт — старостага:] Ни дип кызны качырдың? Ник караусыз калдырдың? Яңагыңа салырмын!* Ш. Маннур.

56. *күч. сөйл.* Эчү (гадәттә исерткеч эчемлекне.) — *Алай күп тә эчмәдем, --- иптәшләр белән бераз кызылны гына салдым.* Н. Фәттах.

57. *күч. сөйл.* Вак тәмәке, эфьюн кебек нәрсәне: тел астында тотып кәефләнү өчен авызга кабу (гадәттә Урта Азиялеләр һәм казакълар, шулай ук кайбер руханилар һәм шәкертләр турында). *Вак салу.* □ *[Көтүче казакъ егет] тагын бер рәт насбай салып алганнан соң йокларга ятты.* М. Гафури. *Әсәрнең каһарманнары — ике мәхдүм. Берсе — Казанда укып, эфьюн салырга өйрәнә алмаган, вә икенчесе дә — Бохараи шәрифкә барып камил эфьюни булып кайткан.* Ф. Әмирхан.

58. *махс.* Машинаны тизлеккә кую, эшләүгә күчерү, көйләү турында. *Агрегатны ходка салу.* □ *Зиннәт машинасын дүртенче тизлеккә салып, газны күп бирде, мотор бар көченә үкерде.* М. Маликова.

59. Күкәйне: үстереп-җитлектереп организмнан чыгару (кошлар, сөйрәлүчеләр, кайбер җәнлекләр һ. б. ш. турында). *Күкәй салмаган тавыкны сую. Ташбаканың күкәйләрен салып комга күмеп калдыруы.* □ *Елан агачка асылынып балалый дип сөйлиләр иде. --- Күкәй сала икән ләбаса ул!* Ш. Маннур.

60. Хайван турында: организмы зарарлану аркасында, баласын вакыты җитмичә (җитлегеп бетмәгән яки ярала гына башлаган хәлендә) тудырырга дучар булу. *Сыерның имгәнеп бозау салуы.* □ *Елга аша чыкканда таеп егылып, бия колын салды.* Г. Ибраһимов.

61. *ярд. ф. функ.* Кайбер фигыльләрдән соң: эшхәлнең тулылыгын, төгәлләнгәнлеген һәм җанлылыгын белдерә. *Кутуй бик объектив кеше, иҗат эшенә хөрмәт белән карый, хәтта үзен тетеп салучыларга да ачу кабартып йөрми.* Г. Кашшаф. *Бер бик тә сәер хәл бөтенләй тетрәтеп салды безне.* Ш. Маннур. || Эш-хәлнең тулылыгын һәм җанлылыгын, шулай ук кыюлык-тәвәккәллекне белдерә. *Шәрифҗан әйтә, рөхсәт ит, ди, мин үземнең егетләрем белән авыл эчендә кырып салам аларны [бандитларны], ди.* И. Гази. *Ну, Булат, малай, егет икәнсең, йөрәктәген әйттең дә салдың.* К. Тинчурин. *Гадәттә ирләр эч серләрен тиз генә ачып салырга яратмыйлар.* М. Максуд.

САЛУ II *ф.* **1.** Өс-башка яки кул-аякка кигән, такканы, бәйләгән һ. б. ш. нәрсәне: чишеп, ычкындырып яки бүтәнчә кире алу. *Бүрекне, бишмәтне, алъяпкычны, галошны, йөзекне, беләзекне, күзлекне, алканы, галстукны, оекны, итекне салу. Бияләй салып эшләү. Су коенганда сәгатьне салып кую. Аркадагы капчыкны салу. Чаңгыны салу. Җиңне сала алмый маташу.* □ *Хәзер әби инде. Тик әле дә Муенсасын салмый муеныннан.* Ә. Юныс. || *сөйл.* Өс-башны, аяк-кулны: чишенү, киемен алу. *Өс-башны салып утыру. Аякны салып керү. Баш салып исәнләшү.*

2. Йөгән, тышау, камыт кебек нәрсәне: ычкындыру, шудырып чыгару, ташлау, аннан арыну (хайван турында). *Атның камытын салуы. Бәрәннең кешәнен салуы. Бозауның муенчагын салып качуы.* □ *[Бия] тынычсызлана, йөгәнен салырга маташа иде.* Г. Галиев. *Туктагач, алар [атлар] пошкырырга, авызлыкларын салырга теләп шылтыратырга, бер-берләренә ышкыныргa, киерелгәләргә тотындылар.* А. Шамов.

3. *күч.* Югалту (табигый төсне, чырайны һ. б. ш.). — *Ул сине --- бөтенләй төсләрен салган, карчыклар төсе керә башлаган инде дип сөйләп йөри.* Г. Камал. *Киленененең Газиз үлгәннән соң һич таушалмыйча, чибәрлеген салмыйча, һаман шулай кызлар төсле матур килеш калуыннан, җыйнак йөрүеннән көнләшә башлады [каенана].* Г. Бәширов.

САЛУ III *и. к.* чалу III. *Кара, ничек шәп юырталар алар [атлар]. Бормадагы салуларда аккош канаты кебек кар сирпелеп кала!* А. Гыйләҗев.

САЛУЛАУ *ф. к.* чалулау. *Минем чана түбән таба салулап китте.* Г. Ибраһимов. *Арба тайгалак юлдан салулап килеп, әйләнеп китте [тау төшкәндә].* Ф. Кәрим.

САЛУЛЫ *с. к.* чалулы. *Салулы борылма.* □ *Аны шахта якларындагы тормыш чанасы салулы юлда аударды.* Каз. утл.

САЛЧЫ *и.* Сал бәйләү һәм агызу эшләрендә эшләүче. *Алар бөтен авыллары белән тимерчеләр дә салчылар. Яздан бөтен ирләре Уралга сал куарга киткәннәр.* Т. Гыйззәт.

САЛЫМ *и.* 1. Дәүләткә халык яки хуҗалык оешмалары түли торган мәҗбүри җыем; налог. *Казан ханының бу җирләрдә моңарчы яшәп килгән җирле халыкларны кысуы, алардан көчләп салым һәм солдат җыюы --- бик табигый хәл.* М. Җәлил. [*Яңгура:*] *Хан миннән салым акчасы көтә.* Н. Исәнбәт.

2. *махс.* Бер салуда, бер оч буйлыктан сугыла торган киндер күләме. *Тоташтан ике салым киндер сугу. Салымны зур итү.*

САЛЫНДЫРУ *ф. Йөкл. юн. к.* салыну (2, 3, 5 мәгъ.). || Түбәнгә сузып асылындыру (аякны һ. б.). *Арбага биш кеше утырган. Боларның берсе, --- иң алда утырып, аякларын тәртә араларына салындырган да дилбегәне тотып бара.* Г. Иделле.

САЛЫНКЫ *с.* 1. Салынып (2 мәгъ.) тора торган. *Салынкы ботаклы чыршы. Салынкы капка. Салынкы ияк.* □ *Ишек алларында яссы гәүдәле, салынкы корсаклы кара дуңгызлар йөри.* А. Шамов. *Аның салынкы кашлары дерелди иде.* Г. Бәширов.

2. Болытлы, бик сүрән, яңгыр алдындагы кебек (көн, һава турында). *Көн салынкы. Авыр соры болытлар авыл өстенә бик түбән төшкәннәр.* Г. Гобәй.

3. Талчыкканлыкны, хәлсезлекне яки иренгәнлекне күрсәтә торган, әкрен (адым, эш-хәрәкәт турында). *Салынкы адым.* || *рәв. мәгъ.* Бик әкрен яки иренеп, теләр-теләмәс кенә (эш-хәрәкәт итү турында). *Салынкы эшләү. Эшнең салынкы баруы.*

4. Әкрен эш-хәрәкәт итүчән, кабаланмаучан, җитезлек күрсәтмәүчән. *Аты салынкының үзе дә салынкы диләр.* Каз. утл.

5. Төшенке күңелле, боек, кәефсез. || Төшенке (күңел, кәеф турында). || *рәв. мәгъ.* Күңелсезләнеп, кәефсезләнеп (йөрү, эшләү турында).

САЛЫНКЫЛАНУ *ф.* 1. Салынкыга (1 мәгъ.) әйләнү, салынып тора башлау. *Ияк салынкылану. Ишек салынкылану.*

2. Болытлау, сүрәнләнү, салыну (көн, һава турында). *Яңгыр алдыннан көн салынкылану.*

3. Бик әкренәю, сулпәнләнү, пассивлану (адым, эш-хәрәкәт турында). *Талчыккан кулның хәрәкәтләре салынкылану.*

4. Әкрен эш-хәрәкәт итүчәнгә, пошмаска әйләнү, сулпәнләнү; җитезлегең кимү. *Эш ахырына таба салынкылана башлау.*

5. Төшенкеләнү, боегу, кәефсезләнү (кеше, күңел, кәеф турында).

САЛЫНКЫЛЫК *и.* Салынкы булу сыйфаты яки хәле, рәвеше. *Гәүдә салынкылыгы. Көзге көннең салынкылыгы. Кәефнең салынкылыгы.*

САЛЫНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* салу I (1—6, 8—10, 12—26, 28—38, 40—52, 56—58 мәгъ.).

2. Сузылып-тартылып, бөгелеп-сыгылып, түбәнгә таба төшеп тору. *Канат салыну. Шәл чуклары салыну. Җилкән салыну. Пәрдә бавы салыну. Түбәдән боз сөңгеләре салыну.* □ *Әнә нинди алмалар, нинди чияләр, агачларын сыгылдырып, салынып торалар.* Г. Бәширов. || Иелеп, бөгелеп төшү (ботак, баш һ. б. турында). *Йокы килгәндә баш салыну.* □ *Карт өянкеләрнең салынып төшкән нечкә ботаклары су эчә.* И. Гази. || Авыша, янтая башлау (кибән, каралты һ. б. ш. турында). *Кибән бер якка салына башлау.* □ *Өй бер якка салынып тора, тәрәзәләре ватык, эче кабер кебек караңгы иде.* Ш. Камал.

3. Гәүдә авырлыгын күтәрә алмас хәлгә килү, аны башкаларга салу. *Аруы җиткәнлектән иренә салына төшеп, Сания аның беләгеннән үзе алган иде.* М. Шабай. [*Авыру*] *Нәҗип бара алмады. Өйдән чыгып берничә адым китүгә чайкала башлады. Аны ике малай ике култыгыннан җитәкләделәр. Ул, барган саен, иптәшләренә күбрәк салына төште.* Г. Гобәй. || Үзең эшләмичә, тырышмыйча, кешегә яки техникага һ. б. ш. ышанып тору, шул башкарыр дип, шуңа исәп тоту. [*Кыз:*] *Мин, апа, иремә генә салынып яшәргә уйламыйм, минем үз һөнәрем булачак.* Г. Әпсәләмов. *Хәзерге кайбер яшьләр чүп утауның ни икәнен белми. --- Мөгаен, химиягә күбрәк салынабыздыр.* Ә. Маликов.

4. Көн, һава турында: болытлау, сүрәнләнү, салынкылану. *Көн салыну.*

5. Юнәлеш килешендәге *-лык* кушымчалы исемнән соң: шундый рухи халәткә бирелү, шуңа сабышу. *Ялкаулыкка салыну. Бозыклыкка салыну.* || Сыйфатлардан һәм *-ган, -мыш* форм. соң: шулай кылану, юри эшләү. *Йоклаганга салынып ятү. Белмәгәнгә-танымаганга салыну. Сизмәмешкә салыну. Ялкау кешенең чирлегә салынуы.* □ *Эш вакытында Гөлнар мине күрми я күрсә дә күрмәгәнгә салына.* Ә. Айдар. *Хөснулла Нәгыйймнең бик ачык әйберне юри аңламамышка салынуын яратмады.* Ш. Камал.

САЛЫШ 1. *сөйл.* Салу (I) фигыленнән (1—4, 6, 8, 10, 12, 16—17, 19—25, 28, 31, 35, 43, 49—50, 52, 56—57 мәгъ.) исем.

2. Салышу фигыленнән (4 мәгъ.) исем.

САЛЫШУ *ф.* 1. *Урт. юн. к.* салу I (1—4, 6—9, 12—17, 19—22, 24—25, 28, 35—36, 40—48, 50—52 мәгъ.).

2. Үзең эшләмичә, тырышмыйча, кешегә яки техникага һ. б. ш. ышанып тору, шул башкарыр дип, шуңа исәп тоту. *Ата-анасына салышып ятучы егет яки кыз.*

3. *-лыкка* формасыннан соң: берәр төрле рухи халәт иясенә әверелү; шуңа бирелү, сабышу. *Тәрбиясез балаларның бозыклыкка салышуы.* □ *Кая гына ләкин китсәк тә без, Сукбайлыкка яшьли салышып, Шул юллардан кире алып кайта Туган йортка йөрәк сагышы.* М. Җәлил. || Сыйфатлардан һәм *-ган, -мыш* формаларыннан соң: шулай кылану, юри эшләү. *Саңгырауга салышу.* □ *Хәлим хатыннарны ишетмәгәнгә, күрмәгәнгә салышып, һич исе китмәгән төс белән башын югары тотып узып китте.* И. Гази.

4. Акчаны: үзара җыешу (күмәк мәҗлес хәзерләгәндә, ярдәм оештырганда һ. б. ш. очракта). [*Тукайны кайгыртучы Вахитов:*] *Дәвалау турында уйларга кирәк.* [*Хәбир:*] *Без уйлашкан идек. Үзара салышырга... Тик бездән җыелган күпме генә була.* И. Нуруллин. *Яшьләр Хафиз белән Хафизаны тәбриклә, Хафизны чөеп, аларны сыйларга алып китмәкче, --- үзара акча салышып, авылга алып кайтырга сыйлар алырга булдылар.* Г. Камал.

САʼЛЬДО *и. махс.* Бухгалтерия кенәгәсендә: дебет белән кредит суммалары арасындагы аерма, шундый калдык.

САʼЛЬТО *и. спорт.* Сикергәндә һавада ясалган мәтәлчек. *Сальто ясап сикерү. Икеле сальто.*

САЛЮТ *и.* 1. Пионерларның махсус тантаналы сәламләве (бармакларын сузып бер-берсенә тидергән

хәлдә уң күл очын баш өстенә күтәрү). *Пионер вожатыеның салютны кабул итүе.*

2. Рәсми сәламләүнең яки хөрмәтләүнең бер төре (мәсәлән, төрле ут коралыннан атып; кылыч, мылтык, флаг күтәреп һ. б. ш.). *Оркестр марш уйный. Табутлар салют астында кабергә төшерелә.* Н. Дәүли. *Яктырттылар безнең өметләрне Тантаналы салют нурлары.* Ә. Ерикәй.

◇ **Салют бирү** — сәламләү яки хөрмәтләү (югарыда әйтелгән рәвештә). *Комсомолларга Салют бирәбез, Алмашка киләбез!* һ. Такташ. *Берничә кызылармеец мылтыктан атып салют бирде.* Г. Гобәй.

САЛЮТЛАУ *ф. сир. к.* салют бирү. *Салютлап каршы алу.*

САМАЙ *с. сөйл.* Гадәттә малай яки тәжрибәсез егет (яисә кыз) дигәнгә каршы әйтелеп, үсеп җиткән, тәжрибәле, олы дигәнне белдерә. *Малайлар арасында иң кызып, иң ярсып эшләгән кеше Исхак булды бугай. Буа янында әвәләнгән ыбыр-чыбыр янына самайларны ул чакырып китергән иде.* А. Гыйләҗев.

САМАН *и.* **1.** Яндырылмый торган махсус кирпеч сугу өчен, үзле балчыкка салам яки тирес һ. б. ш. нәрсә кушып изелгән катнашма.

2. *с. мәгъ.* Саманнан яки шуның кирпеченнән эшләнгән. *Саман абзар. Саман йорт.* □ *Коммуна членнарының затлырак әйберләрен һидият ишек алдындагы саман келәткә җыйнаштырып [куйдылар].* Ш. Камал. [*Исхак*] *лапасның саман стенасын сүтеп, рәтләп яңадан күтәрде.* А. Гыйләҗев.

САМАНЧЫ *и.* Саман ясаучы, шуннан кирпеч сугучы. *Мансур, тәжрибәле саманчы буларак, Бакыйга кайсы төшне ныграк таптарга, ничек таптарга кирәклеген өйрәтте, сыек ләпеккә әледән-әле тирес ташлады һәм кулындагы көрәге белән балчыкны бутап, аралаштырып алды.* Н. Фәттах.

САМБО *и. спорт.* Авырттыру алымнары да кулланып башкарыла торган махсус көрәш; көчлерәк яки кораллы кешегә каршы көрәшкәндә-сугышканда саклану чарасы буларак мәгълүм (*русча:* самооборона без оружия дигәннең кыскартмасы). *Самбо ярышы. Самбо алымнары. Самбо көрәшчесе.*

САМБОЧЫ *и. спорт.* Самбо көрәше остасы, спортчы. *Татарстан самбочылары бу юлы җиңүгә зур ихтыяр һәм осталык күрсәттеләр.* Соц. Тат.

САМИМИ *с. кит.* **1.** Эчкерсез, риясыз, саф күңелле. *Самими кеше.* □ *Артык самими, артык күңелдән дус булган адәмнәр арасында гына була алган бу хәл [хәтер калу] тышкы мөгамәләдә ачуга, дошманлыкка җитәргә мөмкин.* Г. Ибраһимов.

2. Эчкерсезлек-риясызлыкны, саф күңеллелекне белдерә, күрсәтә торган. *Самими сүз. Самими тавыш белән көлү.* □ *Ул Айдарның сөйкемле һәм самими карашыннан мөмкин кадәр исермәскә тырыша.* Ф. Хөсни. || Самимилеккә, эчкерсезлеккә нигезләнгән. *Без яңа гына белешкән кешеләр булсак та, мәҗлесебез бик тиз арада бик самими, әллә кайчаннан бирле бер-беребезне белешеп килгән дуслар мәҗлесе шикелле сурәт кәсеп итте.* Ф. Әмирхан.

САМИМИЛЕК *и. кит.* Эчкерсезлек, риясызлык, саф күңеллелек. *Дминә үзенең ягымлылыгы, шул ук вакытта гаҗәеп бер самимилеге белән бу яшүсмер кызны үзенә каратып өлгергән иде инде.* Г. Минский. *Аның холкында балаларга гына хас самимилек, бер катлы саф чын күңеллелек бар иде.* Г. Бәширов.

САМИМИЯТ *и. иск. кит. к.* самимилек. [*Тукай үлгәннән соңгы көннәрдә редакциягә килгән күп хатларның*] *соң дәрәҗәдә бер ихлас вә самимият белән язылганлыгы күренеп тора иде.* Ж. Вәлиди. *Гыйбадәтханәләр дә юаныч бирмиләр миңа: самимият юк аларда.* М. Максуд.

САМОВАР *и.* Чәй кайнаткыч: үзәктәге утлыгына күмер ягып кайната торган, чиләк сыман ябык металл савыт.— *Рәүфә, әткәң белән миңа кечкенә самоварны, үзегезгә зур самоварны шаулатып җибәр дә дүрт көнлек каймактан май атларга тотын.* А. Шамов. *Самоварга чыра салгансың да, күмер салмый чыгып киткәнсең, самоварың бөтенләй сүнеп беткән.* Ш. Мөхәммәдев.

◇ **Самовар яңарту** — сүнгән һәм суына башлаган самоварны кайнарлау яки яңадан кайнату. *Дворник самоварны яңартып җибәрә.* М. Гафури.

САМОВАРЧЫ *и.* **1.** Самовар кую, чәй әзерләп китерү эшләрен үтәүче хезмәтче. [*Зариф*] *яшь вакытта Казанда дхмәт байда самоварчы малай булып торган.* М. Укмасый.

2. Самовар ясап яки төзәтеп яисә шуның белән сәүдә-кәсеп итеп яшәүче. *Самоварны самоварчыга биреп төзәттерү.*

САМОВАРЧЫЛЫК *и.* **1.** Самоварчы (1 мәгъ.) вазифасы һәм хезмәте.

2. Самоварчы (2 мәгъ.) кәсебе һәм хезмәте. *Самоварчылык белән көн күрү.*

САМОГОН *и.* Ашлык, бәрәңге һ. б. ш. продуктан иң гадиысул белән йортта хәзерләнә торган исерткеч әчемлек; үзең куып ясаган йорт аракысы. *Самогон кайнату.* □ *Сотник өстәлдәге тулы чәшкә самогонны эчеп җибәрде.* Ш. Усманов.

САМОГОНЧЫ *и.* Самогон ясаучы яки шуның белән сату итүче. *Әле кайчан гына Хәсән абзаң караклар тотып, самогончылар аулап йөргән иде.* И. Гази. [*Шәүлихан:*] *Самогончы хатыннарга ялынып йөр имеш.* Т. Гыйззәт.

САМОДЕРЖА'ВИЕ *и.* Элекке Россиядә: чикләнмәгән властьлы патшаның дворян-алпавыт сыйныфларына таянып идарә итү системасы. *Самодержавие изүеннән котылу.* □ *Мирвәли Биктимиров самодержавиегә каршы аяусыз рәвештә көрәшеп, берничә мәртәбә патша төрмәсендә утырды.* Т. Гыйззәт. *Эшчеләр самодержавиегә һәм капиталистларга каршы революцион көрәшкә әзерләштылар.* М. Җәлил.

САМОЛЕТ *и.* Канаты хәрәкәтсез, үзе һавадан авыррак булган, мотор көче белән оча торган машина. *Самолет, моторын да сүндереп тормастан, хәрби кешеләрне, яралы солдатларны төшереп калдырды да шунда ук Казанга очты.* Г. Гобәй.

САМУМ *и.* Гарәбстан һәм Төньяк Африка чүлләрендә: давылдай башланып китеп, тиз туктый да торган үтә коры, кайнар җил.

САМУРАЙ *и.* Япониядә: хәрби югары катлау кешесе; батыр сугышчы. || *сөйл. шелт.* Япон хәрби сугыш чукмары. *Самурай да менә үлемен сизеп, Булмас хыял белән маташа.* М. Җәлил.

САН I *и.* **1.** Предметларны санау-хисаплау, берәмлекләп барлау өчен кулланыла торган микъдар төшенчәсе, математик зурлык. *Ике урынлы сан. Бөтен сан. Вакланмалы сан. Исемле саннар. Уйланма сан. Зур саннар белән эш итү.* □ [*Ат башыдай алтын өчен тиешле акчаны санаганда*] *җепнең очын югалттык, саннарны саташтыра башладык.* М. Гафури. [*Табылдык тәңкәнең*] *урта бер җиренә 7112 саны сугылган.* Г. Сабитов. || *сөйл.* Саннар белән күрсәтелгән мәгълүмат, хисап-отчет, сводка һ. б. ш. [*Хәят:*] *Дни, сезне Зөләйха апа чакыра, бүгенге саннарны сорый.* Ә. Камал.

2. *сөйл.* Микъдар; күләм. *Малларның баш саны арту.* □ *Такташ сан ягыннан зур булмаса да, сыйфат ягыннан зур кыйммәтле әдәби мирас калдырды.* Г. Нигъмәти. [*Низамов:*] *Бәрелеш сәгатендә без дошманны корал көченнән битәр саныбыз белән җиңәргә*

тиеш булачакбыз. Чөнки безнең шартларда җитәрлек күләмдә корал табу бик кыен булачак. Г. Әпсәләмов.

3. *кит.* Вакытлы матбугат басмаларында: номер. *Мәскәүдә Муса Җәлил редакциясендә чыга торган „Октябрь баласы“ журналының һәр санын укып бара башладым.* Ж. Тәрҗеманов.

4. *лингв.* Предметларны санаганда аларның микъдарын яки тәртибен белдергән сүз исеме һәм шундый исемнәрне өйрәнә торган сүз төркеме. *Төп сан. Тәртип саны. Чама саны. Бүлем саны.*

5. *лингв.* Предметның бер генә яки күп булуын белдергән грамматик категория. *Берлек саны. Исемнең күплек санында килүе.*

САН II *и.* Ихтирам, кадер; игътибар. [*Бөлгән бай:*] *Кесәдә акча күп чагында һәр җирдә иде безгә сан.* Ш. Мөхәммәдев.

◊ **Санга алу (санау, сугу)** — санлау; исәпкә-игътибарга алу.— *Бездә чакыргач килмичә ярамый. Кем, ашны санга алмау, хуҗага илтифатсызлык итү була ул.* А. Әхмәт. *Рәүфә белән Нәсимә карчык аңа, кеше итеп санга санап килүе өчен, бик зур рәхмәт әйтеп калдылар.* А. Шамов. *Ат, малайларны санга да сукмыйча, башын ялкау гына селкеп, --- үз җае белән генә килә бирде.* И. Гази. **Санга тыгу** *к.* санга алу (кешеләр турында гына).— *Үзе урысча укыгач та, олыларны санга тыкмый.* Ф. Әмирхан.

САН III *и.* Гәүдәнең берәр өлеше.— *Юк, малай, булмас аннан да, алгы саны биек аның. Алгы аяклары озын булган атның үзганын син һичкайда күрмәссең.* М. Гали. *Алар куяннарның берсен, иң симезен, пешереп ашадылар. Арт санын, иң тәмле җирен, Нәҗипкә керттеләр.* Г. Гобәй. || *сөйл.* Гәүдә. *Хәлимнең Кафияне култыклап алырга кыюлыгы җитмәс иде. Ә Кафия сорап тормады, култыклады, саны белән Хәлимгә орынып-орынып бара.* И. Гази. *Ул санын күтәреп тора алмаслык дәрәҗәдә арганлыгын тойды.* Х. Камалов.

САН- Кушма сүзләрдә „санитария“, „санитариягә мөнәсәбәтле“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **сантехник, сандружина, санэпидстанция, санпост, санбат, санрота, санпоезд.**

САНА *кис., фигыльләр янында кулланыла.* **1.** Үтенүне белдергән фигыльгә ялыну төсмере өсти. *Ачуланма сана, Гайниҗамалым, Сине мин кимсетеп әйтмим лә, җаным.* Г. Тукай.

2. Кирәксенмәү, санламау, ирония беләнрәк карау кебек төсмерләрне белдерә. [*Хәсән — хуҗа кызы турында:*] *Кайтмаса, хәерле булсын сана!* Ф. Әмирхан. [*Гайшә Шакирга:*] *Әйй, кыланма сана.* Ф. Бурнаш.

САНАЛМЫШ *и. лингв.* Саннан соң килеп, аның тарафыннан ачыклана торган сүз. *Саналмышның җөмләдә ия яки тәмамлык булып килүе.*

САНАМ *и.* Мәҗүсиләр табына торган сын, балбал, пот. *Алтын санам.* □ *Стенадагы шүрлектә япон фарфоры әйберләре. --- Уртада зур корсаклы, башы җилкәсенә кереп утырган килбәтсез санам басып тора. --- „Алла“ның баш очына бизәкле матур келәм эленгән.* Ә. Маликов.

САНАМЫШ *и. махс.* Балалар уенын башлаганда тәртип билгеләү һ. б. ш. өчен әйтелә торган кыска такмак (сан сүзләре һәм аваз ияртемнәре кертеп төзелә).

САНАТ *и. иск.* **1.** *к.* сенат (2 мәгъ.). *Әбүбәкер солдат булмаса, кем бу татар җәмгыятенең сүзен санат хәтле санатка үткәзерлек итеп язар да, кем аны шундый югары урынга җиткерергә алыныр иде?* М. Рафиков.

2. *к.* сенатор. *Патшаларын, санатларын... сындырып ташла канатларын; Җәһәннәм төбенә китсен, авызыңа алма атларын.* Г. Камал. *Кызлар башта патшага барам дип, аннан санатка, ахырында солдатка булса да ярар дип әйтәләр ди.* Мәкаль.

САНАТО'РИЙ *и.* Башлыча табигый чаралар (һава, минераль су, диета, гимнастика) белән дәваланып ял итү йорты. *Тау битендә яңа санаторий.* Ш. Маннур. *Әлмәттә бораулаучыларның төнге санатории эшли. Анда дәвалану һәм ял итү өчен бөтен шартлар бар.* Соц. Тат.

САНАУ *ф.* **1.** Саннарны үз тәртипләре белән бер-бер артлы әйтеп бару. *Унга кадәр саный белү.* □ [*Йөгерешүче малайлар*] *бер сызыкка килеп басалар да: „Бер, ике, өч!“ дип санап кузгалып китәләр.* А. Шамов.

2. Предметларның микъдарын бер-бер артлы саннар белән хисаплау; ничә яки күпме икәнне билгеләү. *Акча санау. Сарыкларны төнгелеккә япканда санап кертү. Гер күтәрүченең ничә тапкыр күтәргәнен санап тору.* □ *Кирәк нәрсәләрнең барысын да саный китсәң, шактый җыела.* М. Шабай. *Санап китсәң, очына да чыга алмассың — нәрсәләр генә эшләнми безнең илдә!* Н. Дәүли.

3. Берәр нәрсә яки кеше турында нинди дә булса фикердә булу, аны тегеләй яки болай дип хисаплау, уйлау.— *Сез мине бичарага саныйсызмыни?* Н. Исәнбәт.— *Халык авызыннан чыккан һәрбер сүзне дә дөрес дип санарга ярамый.* Т. Гыйззәт. *Көрәшсез үткән көннәрне әрәм саныйм.* Г. Ибраһимов.

САНАУЛЫ *с.* Саналган; саны билгеле. *Санаулы каз. Санаулы акча.* || *күч.* Бик әз. [*Культурасыз кешеләр*] *хәзер инде бик санаулы гына калып баралар.* Ф. Әмирхан. *Рәхимнең саклык кенәгәсендә бераз җыйган акчасы бар. Ләкин ул да санаулы.* А. Расих.

САНАУСЫЗ *с.* Саналмаган; саны билгесез. *Санаусыз акча булмый.* Сөйл. теленнән. || *күч.* Чиксез күп. [*Ул вакыттан бирле*] *санаусыз гасырлар кичте.* Ш. Камал.

САНАУЧЫ *и.* **1.** Санау (I) хезмәтен башкаручы, шундый эштә эшләүче. *Җыелышта тавыш бирүчеләрне исәпкә алу өчен санаучылар билгеләү.*

2. *мат.* Вакланманың бүленә торган, сызык өстендәге өлеше; *русчасы:* делитель.

САНАШУ *ф.* **1.** *Урт. юн. к.* санау (1, 2 мәгъ.).

2. Берәр нәрсәне яки кешене исәпкә, игътибарга алу, аның белән хисаплашу. *Яшең олы диләр. --- Яшь белән санашыр чакмыни?! Минем көчем бар.* Х. Садрый. [*Камәр*] *кая кушсалар шунда җигелде, эшнең нинди булуы белән санашып тормады.* М. Хәсәнов. *Үз көченә кирәгеннән артык ышану, башкалар белән санашмау --- анархиядән башка бер нәрсәгә дә китерми.* И. Гази.

САНГВИ'НИК *с. кит.* **1.** Җанлы, күңелле, уйнак, хискә тиз бирелеп, тирәнгә китмичә тиз суынучан (кеше һәм холык турында).

2. *и. мәгъ.* Сангвиник темпераментлы кеше.

САНДАЛ I *и.* Җәйге җиңел күн аяк киеменең бер төре (сай читле, аркылы әләктергечле, үкчәсез була). [*Ишектә*] *чәчләре тузгыган, ялан аягына сандал кигән кыз күренде.* К. Нәҗми. [*Солтан*] *аягына юка оек белән челтәрле сандал кигән.* Г. Галиев.

САНДАЛ II *и.* Тимерчелек җиһазы: металлны куеп чүкиләр торган махсус тимер аслык. *Сандал бүкәне.* □ *Тимерче ярдәмчесе аны биш-алты килограммлы чүкечен җилкәсенә салып сандал янында көтеп тора. Сандалның икенче ягына Мәрдән абзый баскан. Ул кыршылып беткән учларына төкереп кечкенәрәк чүкечкә тотына. Менә Мөнип абзый ут эченнән очкыннар чәчеп торган тимер кисәген әләктереп ала да сандалга китереп сала.* М. Шабаев.

САНДАЛ III *и.* 1. Мәңге яшел, хуш исле, эфир майларына бай тропик агач. *Һиндстанда үсә торган сандал агачлары. Сандал мае.*

2. Шушы һәм бүтән кайбер агачлардан алына торган табигый буяу.

САНДАЛИ *и. к.* сандал I. *Аяз чыбыркы сабы белән аягындагы челтәрле сандалиен каккалап алды.* Г. Бәширов.

САНДУГАЧ *и.* 1. *зоол.* Нәфис тавышлы күчмә сайрар кош (коңгырт яки соргылт төстә, чыпчыктан озынчарак). *Яз җырчысы дип сыерчыкларга сокланган, табигатьнең сайрар патшасы дип сандугачларны мактаган кешеләр белән бәхәсләшмим.* Каз. утл. || *күч. шигъ.* Кадерле кешенә иркәләп әйтү сүзе. *Су буенда гөлләр үскән, Кызлар йөргән төштер бу; Сөеп алу, сөеп бару, Галиябану сандугачым, Илдә булган эштер бу.* М. Фәйзи.— *Сандугачым! — диде Газинур, кызны кинәт кочагына тартып.* Г. Әпсәләмов.

2. *с. мәгъ. күч.* Бик күркәм, нәфис, музыкаль (тавыш һ. б. ш. турында). *Каюм җырлап җибәрде. Аңар сандугач тавышлы Фәрдәнә һәм башкалар кушылды.* Г. Гобәй. [*Шәрифулла*] *бу яхшы күңелле, сандугач телле карчыкның кәефен кырмаска тырышты.* А. Шамов.

САНДЫК *и.* Әйбер саклый торган зур (гадәттә озынча) тартма (ачылма өсле, йозаклы). *Агач сандык. Тимер сандык. Акча сандыгы.* □ *Көндез, өйдә бер ялгызы гына калганнан соң, ул Газизе турында уйланып, кулына бер эш тота алмыйча, тынгысызланып йөрде дә, түр яктагы зур сандыкны ачып, Газизнең киемнәрен җилләтергә булды.* Г. Бәширов.

САНДЫКЧА *и.* Кечкенә сандык. *Грун бер иркен вакыт табып хәзинәгә керде. Анда теге сандыкчаны эзләп тапты да карады. Күрде: сандыкчада бер матур кызның сурәте ята.* Ф. Халиди.

САНДЫКЧЫ *и.* 1. Сандык ясау остасы.

2. Сандык белән сәүдә яки сату итүче.

САНИТАР *и.* 1. Авыруларны, яралыларны карау, дәвалау йортын җыештыру һ. б. ш. эшләрне башкаручы кече медицина хезмәткәре. *Санитарлар аларны* [*яралыларны*] *носилкалар белән күтәреп кереп, --- палаталарга менгереп урнаштырдылар.* М. Гали. *Санитарлар аның өстен ачып, ашыгыч бәйләнгән ярасын чишә башладылар, дарулар алып килделәр.* Г. Гобәй.

2. *с. мәгъ.* Санитария эшендә файдаланыла торган. *Санитар сумка. Санитар машина. Санитар поезд.*

САНИТАРИ'Я *и.* Гомуми чисталык һәм сәламәтлекне күзәтү чаралары системасы.

САНИТА'РКА *и.* Хатын-кыз санитар. [*Әбүзәр абзый*], *гадәтенчә, очраган бер кешесе белән, аның врач, сестра яки гади бер санитарка булуына карамастан, ихтирам күрсәтеп исәнләште, авыруларның хәлләрен сорашты.* Г. Әпсәләмов.

САНИТАРЛЫК *и.* Санитар хезмәте һәм вазифасы. [*Ирекле булып фронтка китәргә теләүчеләр:*] *Безне стройга алыгыз. Санитарлыкка бездән картраклар да табылыр әле.* Ш. Усманов.

СА'НКЦИЯ *и. кит.* 1. Берәр эшне, чараны раслап, аны башкару өчен югары органнардан бирелгән рәсми рөхсәт, ризалык. *Югары суд санкциясе.* □ [*Суд тикшерүчесе:*] *Мин Дәүләтшинны кулга алу өчен санкция сорап прокурорга бармадым.* Каз. утл.

2. Халыкара хокукта: килешүне бозучы якка каршы кулланыла торган чара. *Агрессия юлына басучы дәүләткә карата экономик, финанс һәм хәрби санкция куллану.* □ [*Плендагыларны саклаучы:*] *Закон нигезендә, буйсынмаган әсирләр атылырга тиеш. Бүген без бу санкцияне кулланырга хаклы идек.* Н. Дәүли.

СА'НКЦИЯЛӘҮ *ф. кит.* Рәсми рөхсәт, ризалык, санкция бирү (югары органнар һәм оешмалар турында). *Санкцияләүче органнар. Берәр халыкара чараны санкциялә.*

САНЛАУ *ф.* 1. Әйткәнне, кушканны игътибарга, санга алу; тыңлау. *Ата-ананы санлау. Укытучы сүзен санлау.* □ *Өлкәннәрне санлау кирәк.* Ш. Камал. *Ачып бирмәк булам бөтен серләремне, Син аларны санламыйсың, санламыйсың.* М. Җәлил.

2. Буйсыну, тыңлау, карышмау (хайван турында). *Үгезнең көтүчене санлавы.* □ *Яз дәрте белән җиңеләйгән атлар кызларны санламыйча боргалана һәм киреләнәләр.* Г. Бәширов.— *Фермага үзең кайтмый ярамас. Ул* [*айгыр*] *мине генә санлап бетерми.* Ә. Камал.

САНЛАШУ *ф. сөйл.* Берәүнең әйткәнен, кушканын игътибарга, санга алып, аның белән исәпләшү. [*Хатны*] *шунда ук ачып укый башларга яхшысынмадым — мине сыйлыйсы килеп көтеп утырган командир белән, ничектер, санлашмау булыр иде.* Ә. Еники.

САНЛЫ I *с.* Сан яки саннар белән белдерелә, күрсәтелә торган. *Санлы һәм хәрефле дәрәҗә күрсәткечләре. Санлы мәгълүматлар. Санлы диаграмма. Отчеттагы санлы күрсәткечләр.*

САНЛЫ II *с.* Хөрмәтле, авторитетлы. *Минем халкым бөек булса, Димәк, мин санлы кеше.* Ә. Ерикәй. *Табынны мактаган кеше Бездә кабруйлы, санлы.* Р. Харисов.

САНСКРИТ *и.* Борынгы Һиндстанның әдәбият теле. *Санскрит язмалары.*

САНСЫЗ I *с.* Санына-исәбенә чыккысыз; исәпсезчиксез күп. *Җырланмаган сансыз җырлар бар.* М. Крыймов. *Ерак җирләр, сансыз еллар аша Ишетәсең шагыйрь тавышын.* К. Нәҗми.

САНСЫЗ II *с.* 1. Тыңлаусыз, тәртипсез. [*Малайлар*] *кай чакны, балалыкка бирелеп, үенга мавыгып китәләр дә җир өстендә әүмәкләшеп көрәшә башлыйлар яисә атларын ташлап --- тычкан куарга тотыналар. Нәфисә аларны орыша, болай сансыз булсалар, атларын кызларга алып бирәм дип куркыта башлый.* Г. Бәширов. || Юньсез, начар.— *И аллам, бигрәк сансыз нәмәстә булып чыкты ла бу Гөлсем.* Г. Гобәй.

2. Авторитетсыз, хөрмәтсез; кадерсез, кирәксез. *Ялгыз кеше — сансыз кеше.* Мәкаль. *Ил эше, ил көче сансыз калмас, Чын батыр мәйданда дансыз калмас.* К. Тинчурин.

САНСЫЗЛАНУ *ф.* 1. Сансызга, тыңлаусызга әйләнү.

2. Сансызлык, тыңлаусызлык күрсәтү.

САНСЫЗЛЫК *и.* Сансыз, тыңлаусыз кешегә хас сыйфатлар.—*Син нигә минем сәламемне алмыйсың? Күрешмисең дә, ә? — дип гаҗәпсенү катыш гарьләнеп сорады Ситдикъ бай. --- Ул авылда үзенә карата мондый сансызлыкка өйрәнмәгән, күрәсең.* Ә. Фәйзи.

САНСЫНУ *ф.* Санлау, хөрмәтләү. *Җәй көне малайларның кайбер йөрәкләрәге урманнан карчыга баласы тотып кайта. Оясыннан егылып төшкәнгә күрә генә кулга эләккән бу кошчык бөтен авыл малаенда соклану тудыра. --- Теге малайга, бер дә теләмәсәләр дә, сансыныбрак карарга мәҗбүр булалар.* Ш. Маннур. *Чәй янында ул* [*җизнәсе*] *Габдулланы бик сансынып, олы кешеләр белән сөйләшкән кебек сөйләште.* Ә. Фәйзи.— *Бу кадәр дәүләтне ник сансынмыйсың?* Ш. Бабич.

САНТИМ *и.* Франция, Бельгия, Люксембург, Швейцариядә, шулай ук элек француз колониясе булган кайбер илләрдә: франкның йөздән бер өлешенә тигез вак акча.

САНТИМЕТР *и.* Метрның йөздән бер өлешенә тигез озынлык үлчәү берәмлеге.

САНТИМЕТРЛАУ *ф.* 1. Сантиметрга кадәр төгәллек белән үлчәү.

2. Сантиметрлы бүлемнәргә бүлү. *Ул, сөрү катламын үлчәү өчен сантиметрлап ясалган үлчәү таягын Гайҗан агайдан сорап алып, --- сөрелгән мәйданның өстенә кереп китте.* Ф. Хөсни.

САНТИМЕТРЛЫ *с.* 1. Сантиметрлар белән үлчәнә торган.

2. Сантиметрларга бүленгән, сантиметр озынлыгындагы бүлемнәрдән торган. *Сантиметрлы линейка.*

САНТЫЙ *с. сөйл.* 1. Җүләр сыман, тилемсә; җинел акыллы. *Галимә апаның тиле кебек йөрүенә авыл халкы гаҗәпсенми башлады. --- Безнең өй эчендәге кешеләр дә Галимә апаның теге очтагы тиле дхмәт кебек сантыйга әйләнеп китүенә өйрәнгән кебек булып киттек.* М. Гафури. *Сантыйга чын сүз — ул нигә!* М. Максуд.

2. Сантыйлыкны белдереп, сиздереп тора торган (сүз, фикер һ. б. турында). *Сантый сүз.*

САНТЫЙЛАНУ *ф.* 1. Сантыйга әйләнү.

2. Сантый булып кылану; сантыйлык эшләү. [*Әтисе — кызына:*] *Эшең бер дә юкмыни соң синең, балачага кебек аяк арасында сантыйланып йөрмәсәң.* Ф. Хөсни.

САНТЫЙЛЫК *и.* Сантый кешегә хас сыйфатлар. [*Мәпә:*] *Ул көне-төне МТСта чапсын, аңа кыр да стан. Мәпә өйдән чыкмый аны саклап утырсын. Жаным, кара инде бу ирнең сантыйлыгын.* Н. Исәнбәт.

САНӘМ *и. к.* санам.

САП *и.* 1. Корал кебек нәрсәләрдә: кулга тота торган өлеш, тотка. *Балта сабы. Көрәк сабы. Урак сабы.* □ *Назимов эшкә керешер алдыннан чүкечена яңа сап ясады.* Г. Әпсәләмов. *Күпердә, кулына кармак сабы тотып, Салих утыра.* Г. Мөхәммәтшин. || Кайбер куллану нәрсәләрендә: әйберне берәр җиргә эләктереп, кидереп, беркетеп кую өчен хезмәт итә торган җайланма. *Күзлек сабы.*

2. *сөйл.* Үлән үсемлектә: сабак. *Нәзек кенә үлән саплары кояшка таба сузылдылар.* Ф. Әмирхан. || Яфракта: сабакчык, сабакча. *Яфрак саптан һәм яфрак җәймәсеннән тора. Сап ярдәмендә яфраклар сабакка беркетеләләр.* Ботаника.

САПЁР *и.* Армиядә: төзү-корү һ. б. ш. эшләр белгече; шундый частьтагы хәрби хезмәткәр. *Мина кырларында сапёрлар безнең өчен юл ачтылар, маяклар кададылар.* И. Гази. [*Фронтта*] *сапёр идем. Җимерергә дә, төзергә дә туры килде.* Р. Ишморат.

САПЛАМ *и.* Бер тапкыр сапларга җитәрлек җеп турында. *Гөлгенә әби минем ертык күлмәгемне күреп, --- синең тәрбияләр кешең юк. үзеңне үзең кararга өйрән дип, миңа бер инә белән берничә саплам тегәрҗеп һәм ямаулык китереп биргән иде.* Х. Садрый.

САПЛАМЛАУ *ф.* Саплам-саплам итеп аеру (җепне).

САПЛАМЛЫ *с.* Саплам-саплам итеп куйган (җеп турында). *Сапламлы җеп.*

САПЛАУ I *ф.* Сап (1 мәгъ.) ясап кую. *Балта саплау. Чүкеч саплау. Көрәк саплау.* □ *Аның үз чалгысы бар иде. Бәләкәй генә. Бишенче номер. Үзе таптады, үзе саплады.* Э. Касыймов.

САПЛАУ II *ф.* Инәне, сосаны һ. б. ш. нәрсәне: җепле итү, аңа җеп кидерү.— *Ичмасам күзләремнең дә рәте юк, утырсам инә саплый алмыйм.* Ф. Хөсни. [*Станок*] *кызу-кызу эшли. Сосаларны да кулга алып тору юк!— автоматлар үзләре саплыйлар.* Азат хатын. || Җеп кебек нәрсәне: инәгә һ. б. ш. нәрсәгә кертү, кидерү. *Мәрхүм әткәй туксан дүрт яшендә үлде. Туксан икедә үзе җеп саплый, чалгы чүки иде әле* А. Гыйләҗев.

САПЛЫ *с.* Сабы, тоткасы булган; сапланган. [*Бакчачы*] *җиңнен сызганып һәм саплы пычкы, кәкре пәке белән коралланып, эшкә тотынды.* Ә. Еники. *Кызлар, саплы көзгеләр тотып, боргалана, бии башлыйлар.* Н. Исәнбәт.

САП-САЙ *с. Артык. дәр. к.* сай I (1, 2 мәгъ.). — *Кесә ягы сап-сай калган.* Г. Ибраһимов.

САП-САЛКЫН *с. Артык. дәр. к.* салкын (1, 2, 4 мәгъ.). *Рәхәтләнеп эчтек шунда Сап-салкын чишмә суын.* Ә. Юныс. [*Госман*] *сап-салкын елмаю белән әле дсмага вә әле Шакирга каранып басып тора.* Ф. Әмирхан.

САП-САРЫ *с. Артык. дәр. к.* сары I. *Сары, сары, сап-сары, Сары чәчәк саплары.* Җыр. *Җаббар абзый сәкедә авырып ята иде. Сап-сары булып саргайган, күзләре эчкә баткан.* Ә. Фәйзи.

САП-САСЫ *с. Артык. дәр. к.* сасы (1, 2 мәгъ.). *Сап-сасы балык.*

САП-САУ *с. Артык. дәр. к.* сау (1 мәгъ.). [*Карчык — улы турында:*] *Сап-сау көенчә суга китеп үлде.* М. Гафури. *Кибаранә күтәреп баш безнең таш тау, Селкенми дә, кузгалмый да, тора сап-сау.* Г. Тукай.

САП-САФ *с. Артык. дәр. к.* саф II. *Сап-саф һава.*

САП-САҢГЫРАУ *с. Артык. дәр. к.* саңгырау (1 мәгъ.). *Сап-саңгырау кеше дә ишетми калмас аны* [*матур җырлауны*]. Ш. Маннур.

САРАЙ I *и.* 1. Өлешчә яки бөтенләй ябык лапас һ. б. ш. хуҗалык каралтысы. *Утын сарае.* □ [*Әхмәт*] *автомобильне сарайга кертеп куярга әмер бирде.* Ф. Әмирхан. *Мин шул ат белән бер чакрымлык җирдән кирпеч суга торган сарайлар янына балчык һәм ком ташырга тиеш идем.* М. Гафури.

2. Бурап, күбесенчә идәнләп эшләгән абзар (гадәттә бер-ике ат сыярлык була). *Сарайның бер бүлемендә сыер тоту. Нәсел айгырын сарайда асрау.* □ *Тавыклар өчен сарай корырга* [*булдык*]. Ә. Айдар. *Атны урлаткач сарайны бикләү (ягъни бәла-каза килгәч кенә саклык чаралары күрү).* Әйтем.

САРАЙ II *и.* 1. Патшалар, идарәчеләр, дәүләт башлыклары яши торган йорт. *Хан сарае. Король сарае. Президент сарае.* || Зур, иркен эчле, зиннәтле щәп йорт.— *Менә бу сахра байларның сараеннан артык миңа.* М. Фәйзи. *Бушлык җирләрдә зур шәһәрләр төзелә, зиннәтле сарайлар бар ителә.* М. Максуд. || Җәмәгать оешмалары урнашкан зур бина. *Культура сарае. Спорт сарае. Пионерлар сарае.*

2. Монархияле дәүләтләрдә: монархтан һәм аның якыннарыннан торган даирә. *Сарай министры.* □ *Хәлифә, шагыйрьне ишеткәч, һәр якка эзләүчеләр җибәрде. Җәгъфәрне сарай шагыйре итмәкче булды.* Г. Тукай. [*Таһир:*] *Күптән түгел сарай киңәш итте... Хөкем итте мине асарга.* Ф. Бурнаш.

САРАН *с.* 1. Чыгымнар ясау, акча тоту, бурычйомыш бирү һ. б. ш. эштә: тиешеннән артык сакчыл, акчасын-эйберен файдаланырга яки бирергә торырга бик кызганучан. *Саран кеше.* □ — *Алырсың әлфиядән әйбер. Саран да соң инде.* Каз. утл.

2. *күч.* Юн. килеш. сүздән соң: шунда белдерелгәнне эшләргә яратмаучан, артык тыйнаклык күрсәтүчән. *Мактауга саран җитәкче.* □ — *Хат язарга саран картың.* К. Нәҗми.

САРАНА *и. бот.* Суганчалы үсемлекләрнең бер төре; *русчасы:* лилия, саранка. *Нәрсә генә тәкъдим итмәде ул миңа! --- Шешкән җиргә сарана күкәе, аксыргак тамыры тотып тору дисеңме, --- берсе дә калмады!* Н. Фәттах.

САРАНАЮ *ф. к.* саранлану. [*Галим — байларга:*]

Сез телгә төче, сөйләргә юмарт; кесәгә килгәч, сараныясыз. Ф. Сәйфи-Казанлы.

САРАНЛАНУ *ф.* 1. Саранга (1 мәгъ.) әйләнү. [*Кунакка чакырмаган байлардан зарланучы хәзрәт:*] *Бу елларны алар да саранландылар, чакырмый башладылар.* Ш. Мөхәммәдев. || Саранлык күрсәтү, саран булып кылану. *Ишек бавы бер алтын, безнең апай мең алтын; --- Саранланыр чак түгел, бир, җизни, комсызланма.* Г. Тукай. [*Бай улының сөяркәсе:*] *Әллә кулына акча бик төшми микән? Бик саранланып маташа.* Г. Камал.

2. *күч.* Сүздә, мактауда һ. б. ш. артык тыйнакка әйләнү.— *Нәрсә булды соң әле малайга? Юл мажараларын ни рухланып сөйләде дә, кабер турында сүз чыккач, саранланды да калды.* Р. Төхфәтуллин. || Юн. килеш. сүздән соң: шунда белдерелгәнне эшләүдә бик тыйнаклык күрсәтү, аны эшләүне бик киметү. *Сүзгә саранлану.* □ *Ул миңа гел язып тора, мин дә хатка саранланмыйм.* И. Гази.

САРАНЛАШУ *ф.* Саранлык күрсәтү. [*Нурулла:*] *Бигрәк тә юмартланып киттең.* [*Мортаза:*] *Андый эшкә* [*эшчене сыйлауга*] *минем кайчан саранлашканым бар?* Т. Гыйззәт.

САРАНЛЫК *и.* Саран (1 мәгъ.) кешегә хас сыйфатлар. *Агайның йөк өстендә йоклавына килгәндә, аның бу эше саранлыгыннан килә иде.* Ф. Хөсни.— *Күп вакытта син артык саранлык күрсәтәсең.* Ш. Камал.

САРАНЧА *и.* Үлән ашаучы, чикерткә сыман бөҗәк; шундый бөҗәкләрнең өере, көтүе (авыл хуҗалыгы корткычы булган төрләре зур-зур көтү булып күчеп йөриләр). *Һавада сыерчыклар көтүе күренә. Арадан берсе --- теге саранчаны тота да йота.* А. Алиш. *Сәйфулла һаман бер якка агыла торган саранчаларга бармагы белән күрсәтеп:— Ай-яй, Шәрип абзый, бу нәрсәләр күбәеп киттеләр,— диде.* Ф. Әсгать.

САРАФАН *и.* 1. Рус хатын-кызларының милли киеме: иркен тегелгән, уртадан сәдәпле, җиңсез озын күлмәк.

2. Хатын-кыз киеменең җәйге бер төре: гадәттә инбашына тасма гына куелган җиңсез күлмәк. *Ак кофта өстеннән кара сарафан кию.*

САРАФАНЛЫ *с.* Сарафан кигән. *Сарафанлы хатын-кыз.*

САРАФАНЛЫК *с.* 1. Сарафан тегү өчен дигән яки шуңа яраклык, җитәрлек булган. *Сарафанлык ситсы.*

2. *и. мәгъ.* Сарафан материалы. *Сарафанлык алу.*

САРБАЙ *и. сөйл.* Эт (ялгызлык исеме сыйфатында сары этләрнең кушаматы булып та йөри). *Караңгылана. --- Малайлар белән уйнап йөргән сарбайлар күренми.* И. Гази.— *Кузгалдык, җәмәгать, без эшлисе эшне озын койрык сарбай килеп эшләмәс.* Г. Ахунов.

САРГАЙТУ *ф.* 1. Сары төскә кертү. *Идәнне саргайткан чы юу.* □ *Түшәмнән яңгыр үтеп кереп мичне саргайткан.* Г. Гобәй. || Сарыга буяу. [*Хәмидә*] *алтынга манып саргайткан көмеш тәңкәләр тезеп ясалган калфагын янына алды.* М. Гафури.

2. Ябыктырып төссезләндерү яки саргылт төс кундыру (авыру, кайгы һ. б. турында). [*Бизгәк*] *һаман килә дә тота, килә дә тота. Яхшы ук мине саргайтты, киптерде дә, ябыктырды да инде.* М. Җәлил.

3. *күч.* Кайгыга, борчуга дучар итү. *Рәис Мөнирне шелтәләде:— Килмичә, кызны саргайтасың.* М. Хуҗин.— *Син мине ике ел саргайттың, мин алай да көттем.* Г. Әпсәләмов.

САРГАЮ *ф.* 1. Сарыга әйләнү, сары төскә керү. *Көз җитте. Яфраклар саргайды.* И. Гази. *Көз көне һәм кыш буе саргаймый торган чыршы бар.* Г. Тукай. 2. Ябыгудан төссезләнеп, сары яки саргылт төс куну (тәнгә, кешегә һ. б.). *Кайгыдан саргаю.* □ *Гали абзыйның ябык һәм авырудан бераз саргая төшкән йөзенә кызыллык йөгерде.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Бик кайгыру, борчылу. *Ах, бәгырем, син белмисең, саргаям синең өчен.* Җыр. *Сагынганда хат язмыйсың, бу саргайсын дисеңме?* Г. Тукай. *Бер елдан бирле шуны күрергә саргайдым инде.* Г. Мөхәммәтшин.

САРГЫЛТ *с. Кимл. дәр. к.* сары I. *Алсу саргылт нурларын балкытып кояш чыгарга җыена.* Г. Бәширов. *Бу көзге яңгырдан соң үләннәр җәйгечә яшәреп, рәхәтләнеп, иркенләп китмәделәр. --- Ат эзләрендәге, тәгәрмәч эзләрендәге саргылт үләннәр тәмам хәлсезләнеп, җиргә ятып калдылар.* Г. Иделле.

САРГЫЛТЛАНУ *ф.* Саргылт төскә керү, саргылтка әйләнү. *Диңгез төрле төсләргә кереп уйный: әле саргылтланып китә, әле карасу зәңгәр төскә керә.* Каз. утл.

САРГЫЛТСУ *с.* Бераз саргылт төс кергән (ак нәрсәләр турында). [*Журналның бу номеры*] *сугыш елларындагы начар сыйфатлы саргылтсу кәгазьгә басылган. Буявы шактый тонык иде.* А. Шамов.

САРГЫЛТЫМ *с. к.* саргылт.

САРДЕ'ЛЬКА *и.* Кыскарак юан сосиска.

САРДИН *и.* Сельдь семьялыгыннан, ашау өчен аулана торган вак диңгез балыгы.

СА'РЖА *и.* 1. Аркау-буй җепләре кыйгач, диагональ юнәлештә үрелеп тукыла торган тукыма.

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Саржа халат.* □ [*Хатын*] *көрән саржа плащ кигән иде.* Н. Фәттах.

САРКАЗМ *и. кит.* Усал, ачы ирония. *Аның бу сүзләрендәге киная усал сарказм булып яңгырады.* Ш. Маннур.

САРКАСТИК *с. кит.* Ачы ирониялә (сүз, караш һ. б. ш. турында). *Йөгәнсез сөйләнгәнне очрата калса, шагыйрьнең күзендә саркастик чаткы пәйда була.* И. Рәмиев.

САРКО'МА *и. мед.* Яман шешнең бер төре. *Сөяк саркомасы. Мускул саркомасы.*

САРКОФАГ *и.* Борынгы Мисыр, Греция һәм Римда: зур таш табут яки табут хезмәтен үтәгән корылма. *Фиргавен саркофагы.*

САРКУ *ф.* 1. Берәр нәрсә аркылы әз генә үтеп чыгу; әз-әзләп кенә агып чыгып тору. *Бәйләү аркылы кан саркы. Балта тигән агачның суы саркый башлау.* □ *Баржадан мазут саркый бугай, су өстендә яшелле-зәңгәрле ефәк бизәкләр ишәя бара.* К. Нәҗми. *Бер урында боз ярылган, су саркып чыккан иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Кибә төшү, кипшерү, сарыгу. *Юл саркыганны көтеп юлга чыкмый тору.* □ *Сукыр лампага ут кабызып, саркырга куйган чабатамны мич авызыннан барып алдым.* А. Гыйләҗев. || Аяк астындагы сулар һ. б. ш. турында: кибә, кими төшү.— *Төнлә су саркый төшәр, иртәгә иртәрәк кыймылдарбыз.* Каз. утл.

САРПИ'НКА *и.* 1. Шакмаклы яки буй-буй юка киже тукыма.

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән, эшләнгән. *Сарпинка яулык.*

САРТ *и. сөйл. иск.* Үзбәкстанда әлек-әлектән яшәүче үзбәк. *Халык җырлары чын үзебезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кабиләләренең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм.* Г. Тукай.

САРТИР *и. иск. гади с. к.* бәдрәф. [*Бирән байлар*] *чыгып искене бушатыр, бушаткач сузылып ятыр; Көнен сартир, төнен сартир — менә һиммәт ләре, ай-һай!* Г. Тукай.

САРУ I *ф.* 1. Җепне: киләп ясау өчен, киләп агачына махсус чорнау, урау. *Авыз эченнән йомшак кына көйли-көйли, йомгакка уралган җепләрне киләпкә*

саруын, тулып килгән җеп басмасын үстерүен дәвам иттерде [*Сәйдә*]. С. Рафиков. || Гомумән, кая булса да чорнау, урау (җепне, тасманы һ. б. ш.). *Күкрәге тәңкәле бишмәт кигән, башына ак урамал сарган киленчәк Айбала егетне елмаеп каршы алды.* Г. Ибраһимов. || Пәрәвез җебен таратып беркетү (үрмәкүч турында). *Җәтмәне үрмәкүч агач ботакларына сарган.* Ялкын.

2. Берәр җиргә җыелып урнашу, туплану (корт күче турында). *Агачка сарган күчне тубалга җыеп алу.* □ *Күч әкренләп түбәнәя төште. --- Кая да булса туктап, сарырга җыена бу, диде карчык.* Г. Галиев. || *күч.* Урап-чолгап, әйләндереп алу; күп булып җыелу (ишле төркем турында). *Кырмыскаларның агач кәүсәсен саруы. Укучыларның өстәлне сарып алуы.* □ *Кешеләр Якупны сарып алдылар һәм төрле сораулар белән күмеп ташладылар.* И. Гази.

3. Бик күп һәм куе булып тору, еш урнашып һәм бик ишле булып үсү (үсемлекләр, җимешләр, яфраклар һ. б. ш. турында). *Алманың ботакны яфрак күренмәс дәрәҗәдә саруы.* □ *Нинди яме булсын алмагачның, Ак чәчәкләр аны сармагач!* М. Җәлил. *Ауган ташлар да бар анда* [*зиратта*]. *Язуларын яшел мүк сарган, кырып чистартмыйча аерырлык түгел.* М. Рафиков. || Юнәлеш яки төшем килешләрендәге исемнәрдән соң: күп булып куну, утыру (тузан, кар, корым кебек нәрсәләр турында). *Тегермән стеналарын эчтән он сару. Моржага корым сару.* □ *Нарат ботакларына ялтыр бәс сарган.* Г. Мөхәммәтшин. *Юл кырыйларында --- бераз тузан сарган күкбашлар тезелешеп калалар.* М. Хәсәнов. *Ул корым сарган алачыкка барып керде.* И. Гази. || Томалап-каплап алу (томан, болыт кебек нәрсә турында). *Күкне болыт сару.* □ *Зәй буен сарганда күк томан, Хуш исле гөлбакча эчендә Балкый ул* [*әлмәт*] *йолдызлы күк сыман.* Э. Мөэминова.

САРУ II: сару кайнату — 1) эчтә, аш юлында көйдергән-ачыттырган сыман эчкелтем тәм тойдыру һәм авызга күпчегән-эчкелтем су килүгә сәбәп булу. [*Ибрай:*] *Миңа тозлы ярамый. Саруны кайната.* [*Кызлар:*] *Сару кайнаганга акбур шәп була.* Г. Гобәй; 2) ачуны китерү, күнелне борчу. *Бу яңгырны әйтәм, җык тигере, Кайнатты ла инде саруны.* Ә. Юныс.

САРУЛЫ *с.* Сарылган (киләп җебе турында), сарып куелган.

САРУТ *и. бот.* Кыяклылар семьялыгына керүче үсемлекләрнең бер төре; *русчасы:* пырей. *Әткәй үзе җир башындагы сарутны, актамырны чабып арбага тутыра, үзе миңа җавап бирә тора.* Г. Ибраһимов. *Буразналар буйлап сарутлар Сузылып-сузылып җиргә ятканнар.* Н. Баян.

САРУТЛЫ *с.* **1.** Сарут үскән (җир турында). *Ат кирәк сөрергә, ат кирәк... Җир каты, җирләр тын, сарутлы.* С. Хәким.

2. Сарут катнашкан, араларында сарут та булган (үсемлекләр турында). *Сарутлы печән.*

САРУТЛЫК *и.* Сарут (күп) үскән урын.

САРЫ I *с.* Ком, әфлисун, алтын төсендәге. *Пакь итеп юылган сары идәнгә бусагадан ук чуар палас сузылган.* Г. Бәширов. *Гәрәбәдәй сары бал Тора табын балкытып.* А. Әхмәт. *Сары төс — кайгы-хәсрәт төсе бит ул.* Ю. Әминов.

САРЫ II *и.* **1.** Сары төс. *Сарыга буяу.* □ *Галимәнең калфагында бөрчек-бөрчек сары бар.* М. Гафури. *Йөзләремә чыкты инде Сагынуларым сарысы.* Х. Туфан. [*Хәдичәнең*] *йөзенә тоташ сары йөгергән, ябыккан.* М. Хәсәнов.

2. *мед.* Тирене, тәнне саргылт төскә кертә торган бавыр чире; *русчасы:* желтуха. *Сары белән авыручы яки аны кичергән кешеләрнең тәрәтендә, сидегендә яки төкерегендә күзгә күренми торган вак кына вируслар була. --- Авыру кайвакыт җиңел генә, сары төшмичә дә узарга мөмкин.* Соц. Тат.

3. *мед.* Күзнең карасына саргылт төс биреп тора торган күз авыруы; глаукома; *русчасы:* желтая вода.

4. Күкәй агының уртасындагы сары куе матдә. [*Сания Җантәһиргә:*] *Син бөтен сугыш буена йомырка эчендәге сары кебек кенә яшәдең. Сиңа җил дә, яңгыр да тимәде.* Ә. Камал.

Сары май — эретеп туртасы чыгарылган сыер мае. *Абыстай, баламны ормасын-сукмасын дип, һәр көнне иртәге чәйгә --- баласының хәлфәсенә ак оннан сары майда пешкән кабартмалар, төче коймаклар җибәрә.* Ш. Мөхәммәдев. **Сары су** — тәннең авыру урынында җыела торган саргылт сыекча. *Җир астында күп эшләп, таш казармаларда тора торгач, аларның* [*элекке шахта эшчеләренең*] *тән тамырларындагы кызыл каннары агулы сары суларга әйләнгән.* М. Гафури.

САРЫГУ *ф.* Кибә төшү, кипшерү. *Аяк асты сарыгу.* □ [*Яңгырсызлыктан*] *күлләр дә сарыкты.* С. Хәким.

САРЫК *и.* Куышмөгезлеләр семьялыгыннан булган, күшәүче, имезүче вак йорт хайваны; ата женеслесе: тәкә. *Сарык көтүе. Сарык йоны алу. Сарык ите.* || *күч. гади сөйл. хурл.* Бик юаш, булдыксыз, надан һ. б. ш. кеше турында. [*Гаскәр башы — Түләкне качырган сугышчыларга:*] *Ни эшләдегез сез, сарыклар?! Атланыгыз! Куарга!* Н. Исәнбәт.

САРЫКЧЫЛЫК *и.* Авыл хуҗалыгында: сарык асраучылык, шуның белән шөгыльләнә торган тармак. *Сарыкчылыкка игътибарны арттыру.* □ *Әгәр син сарыкчылык киң җәелгән Кавказ, Урта Азия якларына барып чыксаң, күрерсең: анда көтүченең иң якын ярдәмчесе — эт.* А. Расих.

САРЫЛАНУ *ф.* Сары төскә керү; саргаю. *Бит очы сарыланып тору. Сары төшеп чирләгәндә аяк-кул сарылану.* □ *„Кайгы“ның ни сүз икәнен Белмәгән сабый бала Моңая, сагына күрәсең, Ал йөзе сарылана.* Х. Туфан. *Менә көзләр килде тагын сабырланып, Нурлар тулды башакларга сарыланып.* Каз. утл.

САРЫЛАУ *ф. сөйл.* Сары (I) итү, сары төскә кертү. *Буяуны сарылау.*

САРЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сару I (1 мәгъ.)

2. Үрмәле үсемлек һ. б. ш. турында: берәр нәрсәгә чорналу, уралу. *Колмакның агачка сарылып үсүе.* || Уралып, чорналып иярү, ишле булып ябышу (үлән, аның орлыгы һ. б. ш. турында). *Аяк астындагы коры үләннәр, үсеп торган арпалар, бодайлар әкрен генә шытырдап сыналар. --- Чәнечкеле башаклар кулларга, аякларга сарыла, киемнәргә ябыша.* А. Шамов. || Елан һ. б. ш. җанвар турында: берәр нәрсәне гәүдәсе белән чорнап алу. *Аждаһа килеп тә җиткән. Ул агачка сарылу белән Камыр батыр яшеренгән урыныннан чыгып, кылычы белән аның башын өзеп тә төшергән.* Әкият. || Берәр нәрсә янына якын ук килү, елышып-сыенып ук урнашу. *Кызыксынучан кешенең тәрәзәгә сарылуы.*

3. Кочаклау, муенга асылыну һ. б. ш. рәвештә сыену (гадәттә балалар, хатын-кызлар турында). *Ух, авыр соң! Соңгы күрешүебездә Газизәбануым муенына сарыла да елый.* Ф. Әмирхан. *Ул барып эткәсенең тезләренә сарыла-сарыла: — Сугыш туктаганмы, эткәй? — ди.* Ш. Камал. || *күч.* Ирексезләп, әрсезләнеп иярү, яннан китмәү. *Сарылырга гына тора торган егет.* □ *Мин балалар белән бик тиз уртак тел табам, үзләре үк сарылырга торалар.* А. Тимергалин. — *Авылда миңа бер кыз сарылып йөргән иде, мин яшь әле дип, алмадым.* Т. Гыйззәт.

4. Берәр нәрсә яки кеше тирәсенә бик күп булып җыелышу, аны ябырылып чолгап алу. *Чебен балга*

сарылган кебек, һаман Якупка сарылалар [авылдашлары]. И. Гази. *Урамнан узганнар бу йорт турында туктала төштеләр, кайберәүләр бөтенләй коймага килеп сарылдылар.* Ә. Фәйзи.

САРЫЛЫ *с.* 1. Эчендә сарысы булган (йомырка турында; гадәттә сарылымы яки сарысызмы дип сөйләгәндә кулланыла).

2. Сары катнашкан (төс турында). *Зыяның иң элек дикъкатен алган нәрсә — зур мәйданга җыелган халыкның шул дәрәҗәдә куплеге һәм аның сарылы, аклы вә каралы төстә булып, бертуктаусыз селкенеп, бер яктан бер якка чайкалып һәм авышланып торуы булды.* Г. Ибраһимов. || Сары төс катнашкан, берәр өлеше яки бизәге сары булган. *Сарылы күлмәк. Сарылы ситсы.* □ *Ул өстәленә, тәрәзә төпләренә яшелле-кызыллы, сарылы кәгазьләрдән ясаган чәчәкләр тезеп куйды.* М. Әмир.

САРЫЛЫК *и.* Сары (I) булу сыйфаты. *Төснең сарылыгын я аклыгын караңгыда аерып булмау.* || Сары төс. *Атна-ун көн чирләп яткан арада аның йөзенә сарылык иңгән.* Каз. утл.

САРЫМСАК *и.* Суганчалар төреннән булган культуралы үсемлек (бүлбесенең вак-вак бүлемтекле, тәменең төчерәк булуы кебек сыйфатлары белән суганнан аерыла).

САРЫМСАКЛЫ *с.* Сарымсак кушылган, шуны салып әзерләгән (ашамлыклар турында). *Сарымсаклы колбаса.*

САРЫФ I *и. иск. лингв.* Морфология. *Гарәп сарыфы.* □ *Гомәр хәлфә сабакны сарыфтан башлый торган иде.* Ә. Фәйзи. [*Сабагын әзерләүче Хәсән*] *иң өстә ята торган латин сарыфын тартып алды.* Ф. Әмирхан.

САРЫФ II: **сарыф итү** — 1) чыгымга тоту, файдалану. *Туйга күп акча сарыф итү. Йорт салганда барлык запасларыңны сарыф итеп бетерү;* 2) бирү, чыгару (көчне, энергияне һ. б. ш.). *Ул газаплы хисне бастырыр өчен күңеленең бөтен гайрәтен, хыялының бөтен эшлеклелеген сарыф итәргә туры килде аңа.* Ф. Әмирхан. [*Уку*] *өчен күпме көч сарыф итәргә, ни чаклы зиһен кирәк икәнен әйтеп торасы юк.* М. Гафури.

САСУ *ф.* 1. Бозылып, сасы ис чыгара башлау. *Үләксәнең сасуы.* □ [*Баздан*] *әчкелтем-төчкелтем сасыган балык исләре куерып чыга иде.* Ш. Камал. *Кайда, авыл, теге сасыган күлең?* Н. Баян.

2. Сасы ис белән тулу (бүлмә, һава һ. б. турында); сасы ис иярү, сеңү (берәр нәрсәгә яки кешегә). *Машина газлары исеннән урам һавасының сасуы.* □ *Тәмәке төтененә сасып беткән тар гына коридорда --- плакатларны караштырып бик озак йөрде ул.* И. Гази.— *Сасыга тимә, сасыма!* Ш. Мөдәррис.

САСЫ *с.* 1. Бик тәмсез, начар, авырсы (ис турында). *Сасы искә борынны җыеру.*

2. Сасы исе чыгып тора торган; сасыган. *Сасы тирес. Сасы гөмбә. Сасы корт.* □ *Сасы саз эченнән шул вакыт Кара елан килде үрмәләп.* М. Гаяз. || Сасы ис сеңгән, сасы ис белән тулган. *Сасы баз.* □ *Бөркү, тузанлы һәм сасы һава беркадәр сафлана төште.* Г. Әпсәләмов.

3. *и. мәгъ.* Сасы ис. *Тәмәке сасысының киемгә сеңүе.* □ [*Шырпы фабрикасындагы*] *сасыга өйрәнеп киткәнче Җәмиләгә бик авыр булды.* М. Гафури. *Эт кергән икән монда, эт! Фу, сасысы! Борынны яра.* Р. Төхфәтуллин.

САСЫК *с. иск.* 1. Сасы. *Анда этләр байлар гаиләсе Белән бер сарайда яшәсә, Эшче яши сасык подвалларда, Рәхәт күрми үзе үлгәнче.* М. Гафури. — *Сасык кымыз әчмәгез.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Руханилар һ. б. ш. сөйләмендә: кимсетеп хурлау сүзе.

САСЫЛАНУ *ф. к.* сасу.

САСЫЛЫК *и.* 1. Сасы булу хәле.— *Әсин беләсеңме, әптелкәрим дус, мунчала сала торган күлне? --- Аның пычраклыгы, аның сасылыгы, мин сиңайтим,— ходай дошманыңа күрсәтмәсен!* Ә. Фәйзи.

2. Сасы урын. *Караңгыда ялгыш сасылыкка килеп керү.*

САТАШТЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* саташу.

2. Ялгышып, бер нәрсәне яки кешене икенчесе белән бутау. [*Әти*] *зурлар мәктәбенә йөри-йөри укырга-язарга да өйрәнеп алды. --- Тик әле менә язуыгына бик үк дөресләнеп җитә алмый. Һаман „е“ белән „ы“ны саташтыра.* Г. Лотфи. *Җәй артыннан һәр елны, үз вакытын саташтырмыйча, хәсрәтле көз килгән.* М. Максуд.— *Бәлки, ул Хәмитне бөтенләй икенче кеше белән саташтыра торгандыр.* Р. Ишморат.

САТАШУ *ф.* 1. Йокы аралаш яки аң югалганда бәйләнешсез сүзләр сөйләнү. *Егет бер кемне дә танымый, тик авыр-авыр ыңгыраша һәм ара-тирә нәрсәдер әйтә, саташа, ләкин нәрсә әйткәнен аңлап булмый иде.* А. Шамов. *Курка калды Шәмҗамал, чөнки карты төннең-төн буена, теленә нәрсә килсә шуны кычкырып, саташып чыкты.* Ф. Хөсни.

2. Ялгышу, буталу (санаганда, сүздә һ. б. ш.). *Әбиегез әйтә, мин, ди, ике дистә күкәй санаганда да уникә тапкыр саташам, моны белмим дә белмим инде, ди.* Г. Гали. *Карчыкның үз хәле үзенә авыр иде. Көлүгә дә карамады, малайларның шаяруларына да күз салмады, бутап, саташып, ни булганын сөйләп бирде.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Юләрләнү, диванага әйләнү. [*Камали:*] *Туктагыз әле, егетләр, бүген я мин саташканмын, я булмаса сез акылдан язгансыз. Ни дигән сүз ул, йөрәк күйдыру арба тәгәрмәче күйдыру түгел лә ул.* Ф. Бурнаш.

4. *күч.* Берәр нәрсә яки кеше белән бик мавыгу. *Яшьтәшләрем минем бу кадәр китап белән „саташуымнан“, китапта язылганнарга чын күңелдән ышануымнан көлеп, җае килгәндә үртәп тә алгаладылар.* Г. Бәширов. *Ул фәкать шул йортка гына омтыла, --- шул турыда гына хыяллана, шуның белән генә саташа.* Г. Иделле.

САТАШУЛЫ *с.* Саташу катнаш. *Саташулы төш. Саташулы йокы.* □ *Кыз үзенең сөйгәнен җиде ел буенча ерактан иркәләде. Ерактан аны чәчәкләр, гөлләр эчендә үзе белән бергә очраштырып, саташулы хыял эчендә сөйде.* Г. Ибраһимов.

САТЕЛЛИТ *и. кит. кимс.* Берәүгә буйсынган, аның ихтыярын үтәүче, сатлык кеше. *Империализм сателлитлары.*

САТИН *и.* 1. Тыгыз, өсте ефәк сыман ялтыравыклы киҗе-мамык тукыма. [*Әни*] *ул сатиннан „сиңа җиңсез күлмәк белән трусик тегәрбез“ дигән иде.* Г. Гобәй.

2. *с. мәгъ.* Сатиннан эшләнгән, тегелгән. *Сатин яулык. Сатин тышлы мендәр.* □ *— Апам,— дидем мин аңа,— сиңа күлмәкнең менә дигәне: яшел бизәкле сатины булыр,— дидем.* А. Шамов.

САТИ'РА *и. кит.* 1. Усал, ачы көлү; фаш иткеч ирония. *Сатира белән сугарылган шигырь.* □ *Кешелек горурлыгын югалтып түрәләр тирәсендә ялагайланучыларга халык аеруча көчле сатира угы җибәрә, аеруча зәһәр бер ачу белән көлә.* Г. Бәширов.

2. Кимчелекләрне фаш итеп камчылый торган әдәби әсәр. *Гейненың сатирасын укыганда, бу шагыйрь --- колонизаторларны рәхимсез камчылый кебек тоела.* М. Максуд.

САТИ'РАЧЫ *и.* Сатирик әсәр язучы.

САТИ'РИК I *и. к.* сатирачы. *Ул прозаик һәм драматург та, публицист һәм тәнкыйтьче дә, сатирик һәм тәрҗемәче дә.* Г. Иделле. *Совет сатиригының төп бурычы — искелек калдыкларына каршы көрәшү.* Соц. Тат.

САТИ'РИК II *с.* Сатира белән сугарылган (әсәр, сөйләм һ. б. ш. турында). *Сатирик әдәбият. Сатирик әкият. Сатирик плакат.* || Сатираны гәүдәләндерә торган (әдәби образ һ. б. ш. турында). *Сатирик рәсем.* □ *Сатирик образ тормышта очрый торган тискәре күренешләрнең асылын ача.* Соц. Тат. || Сатираны яклый, алга сөрә, шуңа хезмәт итә торган. *Язучының сатирик алымнардан уңышлы файдалануы.* □ *Сатирик юнәлешле бу комедияләр көннең актуаль мәсьәләләрен күтәреп чыгулары, Совет власте дошманнарын фаш итүләре, агитацион рухта язылулары белән аерылып торалар.* Каз. утл.

САТЛЫК *с.* 1. Сатыла торган, сату өчен дип билгеләнгән. *Сатлык товар җитештерү.* □ *— Миндә сатлык печән юк.* Ш. Усманов.

2. *күч.* Акча, мал өчен намуссызлык, хыянәт эшләргә сәләтле, шуңа әзер торучы. *Ояты юк, сатлык юлбасарның Бүген менә йөзе ачылды.* һ. Такташ. *Утерүчеләр дә шушылар яисә шуларның сатлык ялчылары булә түгелме соң?* Ш. Камал.

САТРАП 1. Борынгы Персиядә: үзәктән читтәге өлкәнең (провинциянең) чикләнмәгән властьлы идарәчесе. *Дәүләтьяров, яңа урында бераз баш-күз алганнан соң, губерна партия комитетына [район җитәкчеләре өстеннән] аллы-артлы бернича хат язды. --- Алар монда, борынгы Персия сатраплары кебек, ни теләсәләр шуны эшләп ятканнар, диде.* И. Гази.

2. *күч. кит.* Гаделсез һәм явыз зур түрә турында.

САТУ I *ф.* 1. Билгеле бер хакка бөтенләй бирү. *Магазиннарда төрле әйбер саталар.* А. Шамов.

2. *күч.* Серне һ. б. мәгълүматны: хыянәтчел рәвештә әйтү, белдерү. *Сер сатканкеше кем булыр дип, [кулга алынган Хәбип] күз алдына Яманташ вакыйгаларын берәм-берәм тезә башлады.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Берәүгә карата хыянәт эшләү. *Бик аз гына кешеләрнең кәгафе өчен Бичара ач халыкны һич тә сатмам.* М. Гафури. *Ләкин батыр илен сатамыни, Курку беләмени батырлар?!* З. Мансур.

4. *күч.* Исемне, намусны һ. б. сыйфатларны хурлый торган эш эшләү. *Ата исемен сату. Намусын сатканхыянәтче.* □ *[Яшьләрне фронтка озатучылар:] Авылның данын сатмагыз, егетләр!* Р. Ишморат.

5. *күч.* Берәр төрле мораль сыйфатка, мәгълүматка һ. б. ш. нәрсәгә ия булган кешедәй кылану, шуңа өндәү (гадәттә моңа лаексыз кешеләр турында). *Суфилык сату. Белдәкләлек сату. Акыл сату. Тәкъвалек сату. Мәгърифәт сату. Мораль сату.* □ *Бездә элгәре балаларга дип гел вәгазь, үгет саталар, бөтен [уку] китапларыбалаларны ялыктырып, укудан биздереп бетә торган нәсыйхәтләр, коры авыз сүзләре белән тула иде.* Ш. Әхмәдиев. *Галим исемен алыйм дисәң әгәр, иптәш. Үз кулларың белән эшне капша төптән. Китап белән генә гыйлем сатып йөрмә.* М. Җәлил. *[Йосыф:] Мәнә көлке: комганчыга шәригать сатарга ярый, әбелә торган кешегә ярамый!* Ф. Әмирхан. || Риядан сөйләү (мәхәббәтне һ. б. ш.). *Гыйшык сату.* □ *Ул ниндидер бер бәйрәмдә, сөйгән кызы дип белеп, аның анасына ярты сәгать чамасы мәхәббәт сатканикән.* А. Шамов.

6. *күч.* Сөйләү, тарату (гайбәтне, ялганны һ. б. ш.). *Сафсата, фәлсәфә сату. Дкият сату. Гайбәт сату. Берәүнең яман атын сату.* □ *Безгә мондый ялган сатып йөрүчеләрнә фаш итәргә кирәк.* Г. Кашшаф. *Ул Муллагалинең начарлыгын сату исәбенә абруй казанырга да теләми иде.* А. Расих. || Оештыру, ясау, алып бару (әңгәмәне һ. б. ш.).— *Җиңги, мичен булып беттә инде, әңгәмәңне соңыннан сатарсың.* Т. Гыйззәт. *Тәмәкене иркенләп, тәмләп суыра-суыра гәп сата башладык.* Ә. Айдар.

7. *күч.* Юләрлек һ. б. ш. эшләү, шулай кылану. — *[Исерек хәлдә] йорт алдына чыгып, Гыйлажиның анасын тотканмын да, миңа кызың Гайнияне бир, мин аңа гашыйк булдым, ул — тирә-якта бер кыз дип, ахмаклык сатып беткәнмен.* Г. Ибраһимов. *[Әхмәт — бюрократ хезмәткәргә:] Юләрлек сатмагыз, зинһар өчен.* Ш. Камал.

◇ **Сатып алу** — 1) хак түләп, үз милкенә әйләндерү. *[Зифа:] Юк, [үрдәкне] буш сорамыйм мин, сатып алам. [Әхмәт:] Без, бүләк итеп алсагыз, куаныр идек.* М. Фәйзи. *Мәхәббәтне акчага сатып алып булмый.* Г. Минский; 2) акча, бүләк кебек нәрсәләр биреп, берәүне үз ягына аудару. *[Аклар офицеры] бу төчеләнүләре белән мине сатып алмакчы булган икән.* Г. Гобәй. **Сатып бирү (җибәрү)** — кешеләр белән мөгамәлә итүдә, хәйләдә-үткенлектә берәүдән бик өстен булу турында. *[Искәндәр — булдыксыз егет турында:] Ишәк! Шәрәф бит моны сатып бирер!* М. Фәйзи.

САТУ II *и. сөйл.* Сату (I) эше, сәүдә. *Ул вакытта һәр ел дип әйтерлек Хәсән сату белән Минзәлә, Әрбет ярминкәләренә йөри иде.* М. Гали. *Ун яшьтә чагында агам мине Себер ягына алып китте. Шунда сатуга өйрәндем.* Г. Ибраһимов.

Сату итү, сату сату — сату, сәүдә эше белән шөгыльләнү. *Кызыл мал белән сату итү.* □ *Рәхимнекеләр кибет ачып сату итә башладылар.* А. Шамов. *Базар көр килеп сату итеп ята.* К. Тинчурин. *Ул кеше дару белән сату итә.* Г. Камал.

САТУ-АЛУ *и.* Алу-сату, сәүдә эше. *Сату-алу эшләре белән арып ял иткән сәгатьләрдә [бай] үз газетасын [укый].* К. Нәҗми.

САТУЛАУ *ф. к.* сатулашу. *Ачы сүзле сәүдәгәрләр ат сатулый.* З. Бәшири.

САТУЛАШУ *ф.* 1. Базарда товар алганда-сатканда, эш килешкәндә һ. б. ш. очракта: бәя, аны үзгәртү турында сөйләшү. *Алмаса да, Тимербай һәр нәрсәнең хакын сорашып, хәтта кайбер күңеленә ошардай нәрсәләргә үз бәясен биреп, сатулашып та йөрде.* М. Гали. *Бераз сатулашкач, әби бүлмәне алты сумга бирергә риза булды.* Ф. Әмирхан. *[Базарда] күрше авылларның бай һәм иген чәчә торган кешеләре печән чабу, урак урдыру өчен алдан акча бирергә сатулашалар, печән чабарга көнлек хакы кырык тиен, урак урырга дисәтинәсенә ике тәнкә акча һәм бер пот арыш биреп ваклашалар иде.* М. Гафури.

2. Берәр нәрсәгә ирешергә, файда итәргә теләп бәхәсләшү яки даулашу, ызгышу. *[Хәлфәләр] югары утыру хакында сатулаша, бер-берсен кысташа башладылар.* М. Гафури.

САТУЧЫ *и.* 1. Товар сатуда эшләүче сәүдә хезмәткәре. *Байда сатучы булып эшләү. Универмагның тукымалар бүлегендәге сатучы.*

2. Сәүдәгәр. *Хәзер аның [бай сәүдәгәрнең] каршында кешеләр ике төрле: берсе — сәүдәгәрләр, икенчесе сатучы була алмаган „гади кешеләр" булып күренә башлады.* М. Гафури. *Ерак җирнең базарчылары кичтән үк безнең авылга [базарга] килеп куналар. Иң алдан Зәңгәр Чишмәнең үз сатучылары кайталар.* Г. Ибраһимов.

САТУЧЫЛЫК *и.* Сатучы һөнәре һәм эше. *[Элекке] чуваш халкында сатучылык дигән нәрсә бөтенләй юк дәрәҗәсендә иде.* З. Бәшири.

САТЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* сату I (1, 2, 4—7 мәгъ.). || Сатылмыйча тормау, ятмау; үтү (товар турында).

[*Хакның*] *яртысын акчалата биргәч,* [*сәүдәгәрләр*], *әлбәттә, үзләренә кул булмаган, үтмәс товарны алмыйлар. Яхшы карап, хакын сәүдәләшеп, үзләренә кирәкле һәм сатыла торган маллардан алалар.* Ш. Мөхәммәдев.

2. *күч.* берәр нәрсә хакына даирәңнән, карашларыңнан ваз кичү; хыянәт итү. [*Кызыл фикер:*] *Мин малга сатыла торганнардан түгел.* Г. Коләхметов. [*Галиябану:*] *Эти дә, әни дә Исмәгыйльгә сатылмагайлары дип куркам.* М. Фәйзи.

САУ *с.* **1.** Саулыгы, сәламәтлеге булган; чирле түгел. *Егетнең бите түгәрәкләнеп килә, күз карашлары да үткенләнә төшкән, тотлыгуы да сизелми. Тик сул кулының асылынып торуы гына сау кеше түгеллеген белдерә иде.* Г. Бәширов.— *Безгә сәламәт балалар өчен, сау яшьлек өчен көрәшергә кирәк.* Р. Ишморат.

2. *сөйл.* Исән, тере. [*Искәндәр бай:*] *Гаптерәшиттән колагын тешләтү аркасында гына сау калды бит* [*кызыбыз*]. *Югыйсә, анасы, уйлап кара, сигез балабыз бит: туды — үлде, туды — үлде.* М. Фәйзи. *Авыр җәрәхәтләнгәннән соң сау калуга ышанып булмый инде.* Ш. Усманов.

3. Саумы(сыз). Очрашканда сәламләшү сүзе.— *Саумы, Сөләйман абзый?* Ф. Бурнаш. [*Шәрәф — ялтырап килеп керә:*] *Саумысыз, Искәндәр абзый! Исәнме, Вәлия абыстай!* М. Фәйзи.

◇ **Сау бул (булыгыз)** — 1) аерылышканда, саубуллашканда әйтелә торган сүз. *Сау булыгыз, Ватан сугышында Җиңеп кайтып, исән күрешик.* М. Җәлил.— *Мин сине туктаттым бугай, пароходка төшәргә соңга кала торгансыңдыр, я, ярый, хуш, сау бул, мин монда бераз утырам әле.* Г. Камал; 2) „рәхмәт“ дигәнгә каршы әйтелә торган сүз.

САУБУЛЛАШУ *ф.* **1.** Аерылышканда исәнлек-саулык теләшү, теләү. *Киткәндә Газзән барысы белән ике куллап саубуллашты, үзенең кая эшкә урнашуы турында бик тиз хәбәр итәргә булды.* Г. Әпсәләмов. *Картлар күпер төбендә басып торалар, безнең белән саубуллашып зур камыш эшләпәләрен һаман селкиләр иде.* А. Шамов. || Берәр җир белән аерылышу, аннан китү. [*Закир Галимәгә:*] *Гөрләтеп туй ясарбыз да саубуллашырбыз бу авыл белән.* М. Максуд. *Саубуллашып Казан белән, Без киттек ераклarга.* М. Ногман.

2. *күч. гадәттә ирон.* Берәр нәрсәдне яки кешедне: югалтырга мәҗбүр булу, аны кулдан ычкындыру, аннан мәхрүм ителү. *Ул саулыгы белән саубуллашты.* Ә. Фәйзи.

САУГЫЧ *с.* **1.** Саву (1 мәгъ.) өчен хезмәт итә торган. *Саугыч аппарат.*

2. *и. мәгъ.* Саву җайланмасы, аппараты. *Электр саугыч.*

САУДЫРУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* саву. *Үзең чирләгәндә сыерны күршеләрдән саудыру.*

2. Саугыч аппарат, механизм ярдәмендә саву. *Бүген савымчыларның һәркайсы иллешәр сыер саудыра.* Азат хатын.

3. Саварга ирек бирү, карышмау (савым терлек турында). *Алдына ашарына куйгач кына саудыра торган сыер. Теләсә кемгә саудыра торган кәҗә.* || Сөт бирү, ташланмаган булу (савым терлек турында). *Сөте көннән-көн кими барса да, сыгрыбыз саудыра, бакчадагы бәрәңгебез дә бетеп җитмәгән иде.* М. Әмир.

САУЛАНУ *ф. к.* савыгу. Саулангач, исән-сау йөрсә, кайчан булса да үзе кайтыр диделәр [Гәрәйне]. Г. Мөхәммәтшин.

САУЛЫК I *и.* Сау булу хәле. *Саулык — байлык.* Мәкаль. *Япон сугышына барып кайтканнан соң, Галиулланың саулыгы какшады.* И. Гази.

САУЛЫК II *с.* Ана женестән (бәрән турында). — *Сарык ике бәрән китерде: берсе саулык, берсе тәкә.* Г. Бәширов.

САУРЫЙ, САУРЫ *и.* **1.** Савыр күне. [*Этиләре*] *ике улына да пардан --- куныч кырыена кызыл сахтиян тоткан, үкчәсенә яшел сауры салган читек --- алдырды.* М. Гали.

2. *с. мәгъ.* Шундый күннән яки шуны кушып эшләнгән. *Саурый башлы читек. Саурый үкчә.* □ [*Айсылуның*] *аягында чәмчәле читек, саурый башмак.* Н. Исәнбәт.

САУРЫЙЛЫ, САУРЫЛЫ *с.* Саурый кушып эшләнгән. [*Гыйльметдиннең*] *өстендә буй-буй чапан. Аякларында саурыйлы читек.* К. Нәҗми. [*Этиләре*] *ике улына да пардан --- саурылы үкчәле шыгырдавыклы кәвеш алдырды.* М. Гали.

САУСЫЗ *с.* Саулыгы начар; чирле. *Эти бу вакытта картаеп өлгергән, җитмәсә тагын саусыз да иде.* Ф. Хөсни. [*Лагерьда*] *картрак һәм саусызрак солдатларны, аерым батальоннарга туплап, Голландия, Бельгия һәм Франциянең төньяк ярларына --- җибәрделәр.* Ш. Маннур.

САУСЫЗЛЫК *и.* Авыру булу хәле, чирлелек. *Профессорның саусызлыгы, артык картаеп киткәнлеге, озак күрми торгангамы, Заһитка бик ачык сизелде.* А. Расих. *Безнең үзебезнең шәхси кәефсезлегебез яки саусызлыгыбыз безнең балаларга булган сөйкемле күз карашыбызны үзгәртергә тиеш түгел.* Г. Тукай.

САФ I *и.* **1.** Кешеләрнең һ. б. (гадәттә хәрәкәт итүче) нәрсәләрнең билгеле бер хәрби тәртип белән, тигез ара калдырып урнашкан рәте һәм шул рәвешле тезелеп оешкан төркеме. *Танк колоннасының сафлары. Демонстрациячеләр сафы. Укучыларның сафка тезелеп зарядкага чыгуы.* □ *Кавалеристлар саф саен дүртәр-дүртәр тезәлешеп, ләкин саф тәртибен сакламыйча, таркала төшеп --- юыртып баралар.* А. Шамов. *Бер ай буена Казаннан аерылып торган батальоннарның төз сафлары Казанга керә башлый.* К. Нәҗми. *Җилфердәтеп җилдә галстугын саф алдыннан атлый вожатый.* Г. Хуҗиев. || Хайваннарның, кошларның сафка охшаш рәте. *Озын муеннарын сузып, саф-саф булып тезелешеп казлар кайтып килә.* А. Әхмәт.

2. Театрда һ. б. ш. җирдә: бер сызык буенча урнашкан урыннар. *Алгы сафта Низамидан башкалар урыннарын бушатканнар иде. Ләкин ике кунакка урын җитми калды.* М. Әмир. [*Нәгыймә*] *алга үтте. Кулындагы билеты буенча дүртенче сафка килде.* Г. Ибраһимов.

3. *кит.* Коллектив, даирә, төркем. *Муса Җәлил язучылар отрядының иң алдынгы сафында бара.* М. Максуд.— *Минем партия сафына керәсем килә.* Ә. Айдар.

◇ **Сафка басу** — 1) башкалар дәрәҗәсенә күтәрелеп, алар белән бергә эш-хәрәкәт итә башлау. *Алдынгылар сафына басу;* 2) эшли башлау, эксплуатациягә бирелү (төзелеш объектлары һ. б. ш. турында). *Яңа заводларның сафка басуы.* **Сафтан чыгу** — 1) авырып, имгәнеп яки бүтән сәбәптән эшкә яраксыз булып калу. *Шундый зур эш барганда ничек бер айга сафтан чыгып торасың.* Р. Ишморат; 2) бозылып, ватылып һ. б. ш. сәбәптән яраксыз хәлгә килү. *Бара торгач, Мескен сабан бөтенләйгә чыкты сафтан.* М. Гафури.

САФ II *с.* **1.** Пычранмаган, болганмаган, бик чиста (су һ. б. турында). *Саф сулы күл.* □ *Безнең бу якларда бу чишмә суыннан да саф, тәмле, йомшак су юк.* З. Бәшири. || Тапланып яки тузанланып пычранмаган, керләнмәгән. *Каен әле яфрак кына ярып килә иде — тузан да кунмаган саф, хуш исле яфраклар*

иде. А. Шамов. [*Биек тау башында*] *җем-җем итеп Саф кар күренә.* Ш. Маннур. || Бөркү түгел, җиләс һәм тузансыз (бүлмә, һава турында). *Урманның саф һавасында --- бераз күңел ачмакчы булдык.* А. Алиш. || Болытсыз, томансыз (күк йөзе турында). *Саф күк йөзе ай һәм хисапсыз күп йолдызлар белән бизәлгән иде.* А. Шамов. || Салкынча һәм йомшак (җил турында). *Килеп бәрде биткә сәер саф җил, Җанга рәхәт җиләс, дымлы җил...* Ш. Маннур.

2. Бер иштән генә торган, бүтән ишләр бер дә катнашмаган (химик элементлар, матдәләр, минераллар турында). *Саф көмештән коелган йөзек.* □ *Эшчеләр арасында, кичә табылган алтыннарны ташлардан аерып үлчәгәч, бер пот та утыз биш кадак саф алтын чыгуы сөйләнә.* М. Гафури. [*Дәүләтшин*] *бер фляга алып килде. „Саф спирт. Су катыштырабызмы, әллә шулай да батармы?“* И. Гази. || Бер генә ишле, башка төсләр яки төсмерләр катнашмаган (төсләр турында). [*Колын*] *кара түгел, күк дип тә булмый. Анасы кебек саф бурлы да түгел, ничектер, күгелҗем ак чәчәк төсе кебегрәк булып ялтырап тора.* Г. Ибраһимов. *Саф кызыл нурга уралган Да төрелгән көннәрең! И иректе эшче халкым, Бу синең үз бәйрәмең!* М. Җәлил. || Башка төрләр яки төрчәләр катнашмаган (нәсел, токым турында). *Саф токымлы йөк аты.* || Башка нәсел каны катнашмаган, кан ягыннан башка катлам вәкилләре белән аралашмаган (нәсел, кан турында).— *Мин бит дворян, саф нәселле; ата-ананың рөхсәтеннән башка* [*өйләнә алмыйм*]. М. Җәлил.

3. Яңа яки ял иткәннән соңгы (көч, дәрт һ. б. турында). *Саф көч белән эшли башлау.* || Армаган, ялыкмаган (баш турында). *Рәхәт тынлыкта кәефләнеп, үз алдыма сызгырына-сызгырына үр башындагы терлек каралтыларына таба барам. --- Башым көндезге кебек саф, күңелем тыныч, миңа рәхәт.* А. Расих.

4. Эчкерсез, риясыз (күңел, уй, хис-теләк һ. б. ш. турында). *Сабый елмаюы кебек саф булсын мәхәббәтең.* Г. Хуҗиев. *Мин шат бүген чын-чын күңелемнән, Уйларым саф, якты булганга.* Ш. Маннур. *Шушы саф теләкне үтәгендә, Безнең дуслык тагы да изгерәк!* Ә. Ерикәй. || Бозык түгел, мораль яктан тотнаклы. *Саф яшьләр арасындагы тирән, көчле мәхәббәтнең шулай бөек идеаллар өчен көрәшкә рухландыруы — табигый нәрсә.* Г. Иделле. *Чөнки булса саф киңәшчең, Һәркайда була уңай; Йөз сумыңнан бер киңәшче изге! — Дигән сүз бар бугай.* З. Бәшири. || Гөнаһсыз, гаепсез.

5. Бик ачык яңгырап, яхшы ишетелә торган (тавыш, аваз һ. б. турында). *Кайдан килгән бу абзыйга мондый сирәк очрый торган саф, көчле калын тавыш?* Ә. Еники.

6. Норма-кагыйдәләргә төгәл туры килә торган, дөрес (тел, сөйләм, стиль һ. б. ш. турында).— *Рәхим итегез! — диде ул саф татарчалап, ләкин берникадәр мишәр акценты белән,— хуш киләсез!* А. Шамов. *Телнең саф, аңлаешлы булуы аеруча балалар әдәбиятында зур урын тота.* Ф. Кәрим. || Башка стиль үзенчәлекләре катнашмаган (тел, сөйләм турында). [*Г. Камалның*] *шигырьләре дә саф халык теле нигезендә язылганнар.* М. Гали.

7. Барлык чигерүләрдән тыш булган, кулга тулысынча керә торган (акча, табыш һ. б. ш. турында). *Узган ел әнә безнең колхоз шушы умарталардан гына да егерме биш, утыз мең сум саф табыш алды.* Ф. Хөсни. [*Электр өчен*] *тотылган расход капланмады әле, алдагы елда капланыр дип торабыз. Аннан соң саф файда китәчәк.* Ә. Касыймов.

САФА *и. иск.* Рәхәтлек, ләззәт. *Җәй --- шулай үтә уенда кызыкта, сафада.* З. Ярмәки. *Бу кадәр зәвык вә сафадан, рәхәттән Хәсәншаның аерылып китәсе килмәде.* Ш. Мөхәммәдев.

◇ **Сафа сөрү** — рәхәттә, борчусыз-гамьсез яшәү. *Сафа ник сөрмәдем икән?* Г. Кандалый. *Эшче халык яшәсен, Сөрсен дөнья сафасын.* Ш. Бабич.

САФЛАНДЫРУ *ф.* **1.** Тондыру, чиста, саф итү (суны һ. б. ш.). || Тузаннан, бөркүлектән, төрле ислә рдән арындырып, җилләтеп саф итү (бүлмәне, һаваны). *Әле генә яңгыр явып үткәнгә охшый. --- Барлык пычрак керне үзләренә сеңдергән шикелле, кара-куч-кыл болытлар Себер тракты юнәлешендә бөтерелеп ераклар га баралар. --- Мәликә эби табигатьнең үзүзен шулай сафландыру, бизәп чибәрләтү сәләтенә хәйран калып барды.* К. Нәҗми.

2. Нәселне, токымны яхшыртып, бер төргә генә калдыру. *Нинди нәсел дип тә булмый аларны* [*сыерларны*], *борыннан килгән вак нәсел дә, колхоз вакытында алынган кайбер эре нәселләр дә сугыш вакытында буталып беткәннәр.— Ярамый болай, ди Нургали, эченнән генә көрсенеп,— нәселне тазартырга, сафландырырга кирәк.* Э. Еники.

3. Башны: ял иттерү. *Мәсьәлә чишкәннән соң һавага чыгып башны сафландыру.*

4. Кире хисләрдән, буталчык фикерләрдән арындыру (кешене, күңелне, аңны һ. б. ш.). *Кешене дәртләндерә һәм аның рухын сафландыра торган хезмәт дәрте аларны бөтенләй үзгәрткән, бөтенесен җилкендергән иде.* Г. Бәширов. *Дуслык кешенең күңелен сафландыра.* Г. Әпсәләмов.

5. Тел, сөйләм, стильне: норма-кагыйдәләргә туры килмәгән күренешләрдән арындыру.

САФЛАНУ I *ф.* Сафка яки сафларга тезелү. *Сафланыгыз, бөтен дөнья эшчеләре!* М. Крыйм ов. *Полк командиры, --- сафланып өлгергән сугышчыларны күзәтеп, бер читтәрәк басып тора.* И. Туктар.

САФЛАНУ II *ф.* **1.** Болганудан туктап, тонып чистару (су турында). [*Карт*] *аның төбенә таш җәйгән, тирәсенә имән бура бураган. --- Шуннан соң менә аның* [*чишмәнең*] *суы сафланып, тоныкланып ага башлаган.* З. Бәшири. || Тузаннан, төрле исләрдән, бөркүлектән арыну, җиләсләнү (бүлмә, һава турында). *Шәһәрдәге бөркүлек, тузан, сөрем исләре бетеп, һава искиткеч сафланды.* Г. Әпсәләмов. *Өйнең һавасы җиңелләеп, сафланып киткән шикелле булды.* А. Шамов. *Яңгыр үтә — һава сафлана.* Ә. Ерикәй. || Болыттан, тузаннан арынып, ачылу (күк йөзе турында). || Йомшакланып, бераз салкынчалану (җил турында).

2. Ял итү, хәл алу (баш турында). || Кире хисләрдән, буталчык яки начар уйлардан, бозык ниятләрдән һ. б. ш. арыну. *Аң сафлану.* □ *Түтәйнең шул күңел әчесен басу өчен бераз бушанасы, сафланасы килә иде.* Э. Касыймов. *И сихерле, серле, илһамлы, гажәеп мандолин!.. Әйдә сыздыр, әйдә сыздыр, сафланыйм.* Ш. Бабич.

3. Эчкерсезләнү, риясызга әйләнү (күңел, уй, хис, теләк һ. б. ш. турында). *Яхшы музыка тыңлаганнан соң күңелеңнең сафланып калуын тоясың.* Г. Бәширов.

4. Бик ачыклану, яңгыравыкка әйләнү (аваз, тавыш турында). *Минем тавышым сафланыр, матурланыр.* М. Максуд.

5. Тел, сөйләм, стиль турында: норма-кагыйдәләргә туры килмәгән күренешләрдән арыну. *Әдәби тел сафлану.*

САФЛАУ *ф. к.* сафландыру. [*Давыт*] *ишек-тәрәзәне ачып һаваны сафлады.* Г. Ибраһимов. *И минем күңелемне сафлаучы мөкатдәс мандолин, Сине тыңлап күзләрем саф яшькә манчып алгалыйм.* Ш. Бабич.

Күңелем сафлады бу хөрлек ялкыны, Нур чолгады алдымны һәм артымны. З. Байчурина.

САФЛЫ *с.* Сафка (I) яки сафларга тезелгән. *Сафлы колонна.*

САФЛЫК *и.* 1. Саф (II) булу сыйфаты яки хәле. *Бүлмәдәге һаваның сафлыгын күзәтеп тору. Алтынның сафлыгын белү. Токымның сафлыгын саклау. Башның, зиһеннең сафлыгы озак дәвам итү. Җырчы тавышының сафлыгына соклану. Тел сафлыгын саклау.* □ *Табигатьнең иртәнге сафлыгына, матурлыгына сокландым.* И. Гази.

2. Эчкерсезлек, риясызлык, намуслылык. *Беренче мәхәббәтнең сафлыгы.* □ *Кайбер ипташларнең политик сөртенүләре һәм мораль сафлыкларын югалтулары күп кенә очракта әнә шул шәхси милек коллыгына төшүләреннән килеп чыга.* Ә. Еники. || Эчкерсезлек, риясызлык билгесе. *Аларның барысының да йөзләрендә — сафлык.* А. Әхмәт.

САФСАТА *и.* 1. Гадәттә артык озын, ләкин әһәмиятсез, кирәксез яки буш, мәгънәсез сүз, сөйләм. *Шигырьдә үгет, нәсыйхәт, сафсата бетәргә тиешле.* Һ. Такташ. || Ялган сүз, хәбәр, уйдырма. [*Дошманнар*] *үзләренең бөтен фронт буйлап чигенүләрен „сугышлама оборона", „фронт сызыгын аңлы рәвештә кыскарту" кебек төрле сафсаталар белән акларга маташалар иде.* Г. Әпсәләмов. || Кирәксез, мәгънәсез һ. б. ш. әсәр. *Динчеләрнең Каюм Насыйри әсәрләрен урам теле белән язган сафсаталар дип каршы алуы.*

2. Хурлап тиргәү сүзе. *Хәзрәт көлде: — Һи, һи, һи, ахмак, сафсата, андый нәфис бармак белән чиртәннән борын шешәме соң!* Ф. Әмирхан.— *Ул сафсаталарны күреп сөйләшәсе иде бит.* Т. Гыйззәт.

САФСАТАЧЫ *и. сир.* Сафсата сөйләүче; сафсата сатучы.

САФЬЯН *и.* 1. Кәҗә яки сарык тиресеннән эшләнгән юка һәм йомшак күн.

2. *с. мәгъ.* Шундый күннән яки шуны кушып эшләнгән, тегелгән. *Сафьян читек. Сафьян тышлы китап.* □ *Кибеттә Галәветдингә иң кыйммәтле, матур әйберләр — яшел буйлы сары ефәк җилән, --- көмеш дагалы сафьян итек алалар.* Мең дә бер кичә.

САХАРИН *и.* Ак порошок хәлендәге татлы (шикәрдән 500 мәртәбә татлырак) матдә, шикәр суррогаты (организмда үзләштерелми).

САХАРИНЛАУ *ф.* Сахарин катнаштыру.

САХАРИНЛЫ *с.* Составында сахарин булган, сахарин катнаштырылган. *Сахаринлы су. Сахаринлы сироп.*

САХРА *и. к.* сәхрә. *Чыгып баш калкыта сахрада уҗым.* Г. Тукай. *Ак күлмәгең бармы синең сахрада кия торган?* Җыр.

САЧ *и. иск., шигъ. к.* чәч. *Гажәп зифа кара ефәк сачларың бар.* Г. Кандалый. *Безнең җанкай сачын тарый гөлдән тамган май белән. Дәтер сүзен әйтә алмады, әйтер әле җай белән.* Җыр.

САЮ *ф. иск.* Санау, хисаплау. *Һөнәрлесең, диде төлке, һөнәрле, Аз эш саймам ул эшне мин дә, кордаш.* Дәрдмәнд.

САЯРУ *ф. диал.* Саегу. *Һәр көн бай баласының, кесәсеннән ничә йөз сумнар чыгып торгач, тагын кесәсе саяра башлады.* Ш. Мөхәммәдев.

САҢАК *и.* Балык һәм кайбер су хайваннарының суда эрегән кислородны сулау органы. *Малай балыкларны саңакларыннан җеп белән асып --- күтәреп китте.* Г. Гобәй.

САҢГЫРАУ *с.* 1. Ишетү тойгысыннан мәхрүм калган, бөтенләй ишетми яки бик начар ишетә торган. [*Камали:*] *Нинди тавыш бу?* [*Шәрифә:*] *Юк, болай гына.* [*Камали:*] *Нинди болай гына? Әллә сез мине саңгырау дип беләсезме?* Ф. Бурнаш.

2. Яңгырап ишетелми торган, басынкы, тонык (авазлар, тавышлар турында). *Йомшак агачка бәргән төсле саңгырау тавыш ишетелде.* Ш. Камал. *Ерактагы яшен чаткылары күк күкрәүнең саңгырау авазлары белән алмашына.* Ш. Хөсәенов.

3. *лингв.* Тавышсыз әйтелә торган, пышылдап та әйтеп була торган (авазлар турында); *киресе:* яңгырау. *Саңгырау тартыклар.*

САҢГЫРАУЛАНУ *ф.* 1. Саңгырауга әйләнү, ишетмәс хәлгә төшү.— *Тукта әле, карчык, ул кадәр кычкырма әле, зинһар,— диде Шәмгун карт. --- Колакны авыртырасың. Әле дә бу колагым саңгырауланды инде.* А. Шамов. [*Низамов:*] *Мин дә --- бомба шартлау, снаряд сызгырудан яртылаш саңгырауланып тупасланган кеше.* Ф. Кәрим.

2. Саңгырау булып кылану.

3. Саңгырауга (2 мәгъ.) әйләнү, басынкы, тоныкишетелә башлау (төрле тавышлар турында). *Әле генә ачыграк ишетелгән кебек тавышлар да кинәт саңгырауланалар.* К. Нәҗми.

САҢГЫРАУЛАШУ *ф. лингв.* 1. Тарихи үсеш чорында саңгырауга әйләнү (авазлар турында).

2. Билгеле бер позициядә: саңгырау булып әйтелү (авазлар турында). *Сүз азагында килгән „б" һәм „д" авазлары, татар теленең фонетик законы буенча, саңгыраулаша.* Ш. Рамазанов.

САҢГЫРАУЛЫК *и.* Саңгырау булу хәле. *Алдагы урыннарның берсендә, саңгыраулыгы сәбәпле, ишетми калмагаем дип, уң колагы белән алга таба иелеп утырган --- карт бригадир урынынан кузгалды.* Г. Бәширов.

СБОР *и.* 1. Пионер оешмаларында: җыелыш. *Дружина сборы. Отряд сборы. Звено сборы.* □ *Әби, без сине пионер сборына чакырырбыз әле.* А. Әхмәт.

2. Кыска сроклы хәрби өйрәнү хезмәте. *Хәрби сбор. Бер айлык сбор. Командирлар сборы.* □ *Ярты гомерең үтә сборларда, Кайчан гына тыныч яшәрсең?* Р. Гәрәй.

СБРУЙ *и.* Ат җигү дирбиясе. *Аның борыннан да атлары бик яхшы, арба вә сбруе бик шәп иде.* Г. Ибраһимов. *Атларны агач ышыгына салынган араннарга ябып, сбруйларны җыйнап куйганнан соң,* [*эшләүчеләр*] *учак тирәсенә таба җыела башладылар.* Г. Бәширов.

СБРУЙЧЫ *и.* Сбруйларны әзерләү-булдыру, төзәтү, карау һ. б. ш. эшләр башкаручы.

СВА'СТИКА *и.* Чатлары туры почмаклап бөгелгән тәре сыман билге (соңгы вакытта — герман фашизмы эмблемасы). *Беләгенә свастика бәйләп йөргән татар фабриканты Яушев завод сакчылыгына „үз кешеләрен" китерүгә --- бик сөенгән.* Ш. Маннур.

СВА'СТИКАЛЫ *с.* Свастика билгесе төшерелгән (төрле рәсемнәр, эмблемалар һ. б. ш. турында). *Свастикалы немец танкысы аеруча ачык күренә, чөнки ул алгы кырый янында ук шартлатылган.* Г. Әпсәләмов. || Шундый билге таккан (кешеләр турында). *Муса үзе таш капчык дип атаган бу салкын базда, свастикалы палачларның җәбере, газаплаулары, кыены астында ул „кырык үлем" кичерә, картая, чәчләре агара.* Г. Бәширов.

СВЕРЛО *и.* Станокка яки берәр механизмга беркетеп әйләндерелә торган тишкеч, борау (металл, агач һ. б. төр материалга түгәрәк тишек яки чокыр ясау өчен хезмәт итә). *Токарь җиңел генә итеп --- сверло белән җизне шаулатып тишеп алды. Менә ул зур сверло өстенә кечкенәсен, күзгә чак күренеп тора торганын куйды. Җизне тагы тишә.* А. Расих.

СВЕТОФОР *и.* Яшел, кызыл, сары яктылык сигналлары бирелә, урамнарда, юлларда тәртипле хәрәкәт саклау өчен куелган электрик фонарь. *Тимер юл*

светофоры. □ *Зур урам чатына җиткәч, светофорда яшел ут кабынганын көтеп бераз тукталып тордык.* Ә. Маликов.

СВИ'ТЕР *и.* Биек якалы, изүсез, бәйләгән җылы фуфайка. *Егетләрнең чаңгы шуарга свитер киеп чыгуы.* □ [*Кызның*] *өстендә зәңгәр йон юбка белән тәненә ятышып торган* [*сыек соры*] *төстәге свитер, иңбашында кыйммәтле мамык шәл.* Ә. Еники.

СВО'ДКА *и.* Агымдагы мәгълүматларны туплап, тәртипкә салып күрсәтә торган язу, белешмә. *Көнлек, айлык, атналык сводка. Бригадир сводкалары. Сводка бирү.* □ *— Бу турыда сводка да юк әле, миңа яралы сугышчылар сөйләде. Финнарны кызган табага бастырганнар! — дип аңлатып бирде Газинур.* Г. Әпсәләмов. *Гөлсем апа --- яралы солдатларга Совинформбюро сводкалары, китаплар укый, хатларын язып бирә.* Г. Гобәй.

СЕАНС *и.* 1. Билгеле бер вакыт дәвамында тоташтан, өзмичә күрсәтелә-карала яки башкарыла торган тамаша, күренеш. *Киноның балалар сеансы. Кичке сеансларның соң бетүе. Гроссмейстерларның күп тактада шахмат сеанслары үткәрүе.* □ [*Шәйгали*] *татар, рус көйләрен бик оста уйный. Үткән ел шәһәр киносында берничә сеанс аның музыкасы астында барган.* Ф. Кәрим.

2. Берәр эшне, чараны мәгълүм вакыт дәвамында тоташтан, өзмичә башкару, эшләү. *Гипноз сеансы.* □ [*Космик*] *автомат станция белән алтмыш радиоэлемтә сеансы үткәрелде.* Соц. Тат.

СЕБЕРЕЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* себерү.

2. *тирг.* Түбән, бозык тормыш алып бару. *Мәликә синең көмәнеңне Сафадан булмаган дип әйтә икән, диләр. Ул бездән киткәнче үк башкалар белән себерелеп йөргән иде, бездән киткәч тә һаман себерелә дип әйтә икән, диләр* [*гайбәтчеләр*]. А. Шамов.— *Балабыз да көпә-көндез илдән качып чит илләрдә себерелеп йөрми.* М. Фәйзи.

СЕБЕРКЕ *и.* 1. Чыбык яки каты үсемлек сабакчыкларын бәйләм итеп ясаган, чүп һәм тузан себерә торган әйбер. *Себерке бәйләү. Урам себеркесе. Дрем себеркесе. Саплы себерке. Себерке белән идән себерү.* || Малга кыш ашату өчен җыеп бәйләнә торган яфраклы чыбыклар бәйләме. *Мал себеркесе.* □ *Бәрәннәргә юкә себеркесе кертәсе бар.* Г. Бәширов. *Бәрәннәрнең сөйгән азыгы булган яфраклы себеркеләрне җәйдән үк йөк-йөк хәзерләп куялар.* А. Расих. || Мунчада чабыну өчен бәйләнгән яфраклы чыбыклар бәйләме. *Мунча себеркесе.* □ *— Кичә генә урманнан алып кайткан, мәтрүшкә катнаштырып җыйган яшь каен себеркесе куйдым, туйганчы рәхәтләнеп чабыныгыз! — диде ул.* М. Гали.

2. *күч. гади с.* Бозык тормыш алып баручы түбән кеше. *Гайнияне алдында да, артында да, кеше ирләрен аздыручы себерке, дип кенә атап йөртә иде* [*Маһибәдәр*]. Ф. Хөсни. *Аракы коллары, тәмәке чуманнары, җилфердәгән һәр итәк артыннан кәс-кәс китүче себеркеләр йортка баш була аламы?* А. Гыйләҗев.

СЕБЕРКЕЛЕК 1. *с.* Себерке бәйләү өчен дип билгеләнгән, шуңа яраклык яки җитәрлек булган. *Себеркелек чыбык.*

2. *и.* Себеркегә дигән, шуңа яраклык яки җитәрлек материал. *Урманнан себеркелек төяп кайту.*

3. *и.* Себеркегә яраклык агач һәм үлән (күп) үсә торган урын.

СЕБЕРКЕЛӘҮ *ф.* Себерке итеп бәйләмләү. *Туйра себеркеләү.*

СЕБЕРКЕЧЕ *и.* Себерке бәйләү, аларны сату белән шөгыльләнүче.

СЕБЕРКӘЧ *и. бот.* Кайбер үсемлекләрнең себерке формалы оешма чәчәге; *русчасы:* метёлка. *Солы себеркәче.*

СЕБЕРТМӘ *с.* Карны, җир өстендә яткан башка вак нәрсәләрне очыртып, астан гына исә торган (җил, буран турында). *Себертмә буран чыккан, инде юлга да сала башлаган иде.* М. Шабай.

СЕБЕРТҮ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* себерү (1 мәгъ.).

2. *к.* себерү (2 мәгъ.). *Көн ныкыны салкын. Кар бераз себертә.* Х. Кәрим. *Йомшак кар яуган көн иде. Әмма төньяктан әз генә җил чыгып тора, кичкә себертә башлавы мөмкин.* М. Шабай.

СЕБЕРҮ *ф.* 1. Себерке, канат кебек нәрсә белән сыпырып, әйбернең, урынның өстен чүптән, тузаннан арындыру, тазарту. *Су бөркеп идәнне себереп алу.* □ *Дворниклар иртә белән кояш чыкмас борын ишек алларын, капка төпләрен себереп куялар.* Ш. Мөхәммәдев. || Чүпне, тузанны себерке яки бүтән нәрсә белән сыпырып алып китәрү, бетерү. *Идәндә балалар ясаган чүпне канат белән себереп алу. Итекка ияргән карны себерү.*

2. Карны, җир өстендә яткан башка нәрсәләрне очыртып, астан гына исү (җил, буран турында). *Салкын җил чыгып тора. Ул каты кар бөртекләрен себереп китереп тәрәзәләргә бәрә, койма буйларына өя.* А. Шамов. *Сары яфракларны себерә-себерә әкрен җилләр исә як-яктан.* Ә. Ерикәй. *Вакыт-вакыт тәрәзә артында җил улый, буран себерә.* Соц. Тат. || з-сыз. Җилнең астан гына, карны һ. б. нәрсәләрне очыртып исүе турында.

3. *күч. сөйл.* Бөтенләйгә куып җибәрү, сөрү. *Себер дошманны җир йөзеннән!* Ә. Ерикәй. [*Батырлар*] *Дошманны илдән, Берен калдырмыйча, куган, себергән.* М. Гафури.

СЕГМЕНТ *и. мат.* Түгәрәктә: дуга һәм аның хордасы белән чикләнгән өлеш, мәйдан; шарда: кисеп үтүче яссылык белән чикләнгән өлеш. *Түгәрәк сегменты.*

СЕГРЕГА'ЦИЯ *и. кит.* Негрларны һ. б. „төсле“ халыкларны „ак тәнле“ләрдән аеру күренеше, хәле һәм политикасы; раса дискриминациясенең бер төре.

СЕЗ *а.* 2-зат, күпл. || Берәүгә (гадәттә чит кешегә) турыдан-туры мөрәҗәгать иткәндә ихтирам йөзеннән кулланыла.— *Инди матур карыйсыз Сез, Разия! Сезнең күзләрегездән гөнаһсыз җаныгыз, пакь йөрәгегез күренеп тора.* Ф. Әмирхан. [*Әнвәр:*] *Син, Мәдинә, кызык кына... Миңа һаман Сез дип эндәшәсең. Ике ел буена таныш кеше белән алай сөйләшү килешеп бетми.* К. Нәҗми.

СЕЗОН *и.* Елның берәр төрле табигать үзгәреше белән аерылып торган яки берәр эш һ. б. ш. өчен уңайлы булган бер вакыты. *Җәйге сезон. Кышкы сезон. Урман сезоны. Ау сезоны башлану. Футбол сезоны ачылу. Җиләк-җимеш сезоны.* □ *Кавказда курорт сезонының гөрләп торган чагы* И. Гази. *Инди сезонда күлмәккә нинди төс, нинди материя тап килүе турында* [*кибетче*] *үз фикерен әйтә.* Р. Төхфәтуллин.

СЕЗОНЛЫ *с.* 1. Елның бер вакытында гына була торган (эш һ. б. турында). [*Нәфисә:*] *Без, татар эшчеләре, бигрәк тә сезонлы эштәгеләр, завод тормышы белән аз кызыксынабыз.* С. Баттал.

2. Сезонлы эштә генә, вакытлы гына эшләүче (эшче турында). *Авылда җирсезлектән һәм алпавыт изүеннән җәфа күреп, шәһәргә килеп, шәһәрдә сезонлы кара эшче булып эшләүче ярлы семьялар бу әсәрдә реаль образлар аша матур бирелгәннәр.* М. Җәлил. *Тәмәке тартып утыручы сезонлы эшчеләр,* [*җитәкчеләр*] *килеп керү белән, мыштым гына барактан чыгып өмәгә киттеләр.* А. Расих. || Аерым берәр сезон өчен генә билгеләнгән. *Сезонлы ял йорты. Сезонлы*

ресторан. □ *Ерак җәйләүләрдә сезонлы кардалар эшлисе бар.* Р. Төхфәтуллин.

СЕЗОНЛЫЛЫК *и.* Сезонлы (1 мәгъ.) булу хәле, сезонлап эшләү-эшләтү тәртибе. *Хәзер --- юллар төзү эшендә сезонлылык бетерелде.* М. Хәсәнов. *Тракторның җитештерүчәнлеген арттыруның мөһим резервы — парктан файдалануда сезонлылыкны бетерү.* Соц. Тат.

СЕЗО'ННИК *и. сөйл.* Сезонлы эшче. *Донбасска ел саен авылдан ун меңнәрчә сезонниклар бара.* Һ. Такташ. *Шәһәр төсле шахта бистәсе Язгы яшеллеккә уралган, Үзгәргәннәр хәзер бөтенләй Сезонниклар йөргән урамнар.* М. Сөндекле.

СЕЙМ *и.* Польша Халык Республикасында: дәүләт властеның югары органы. || Финляндиядә: парламент. || Элекке Көнчыгыш Европаның кайбер феодаль дәүләтләрендә: сословиечел вәкиллекле орган.

СЕ'ЙНЕР *и.* Балык аулый торган кечкенә диңгез судносы. *Монда балык бик яхшы әләгүчән булса кирәк, тирә-юньдә сейнерлар мыж килеп торалар.* С. Сабиров.

СЕЙСМИК *с. махс.* Җир тетрәү күренешләренә мөнәсәбәтле. *Сейсмик карта. Сейсмик лаборатория. Сейсмик тикшеренү.* □ *Шушы төнне бөтен дөньядагы сейсмик станцияләр Кыялы таулар тирәсендә җир тетрәвен билгеләп калдылар.* А. Тимергалин.

СЕЙСМО'ГРАФ *и.* Тетрәү һәм шартлаулар вакытында җир кабыгының тирбәнүен язып бара торган корал, аппарат.

СЕЙСМО'ЛОГ *и.* Сейсмология белгече.

СЕЙСМОЛО'ГИЯ *и.* Җир тетрәүләрне, шартлауларны өйрәнә торган фән тармагы. *Җир тетрәү прогнозы бик зур әһәмияткә ия. Хәзерге сейсмология өчен бу проблеманы хәл итү аеруча авыр нәрсә.* Соц. Тат.

СЕЙФ *и.* Акча, документ һ. б. кыйммәтле нәрсәләр саклау өчен, янмый торган, корыч шкаф, тартма яки махсус бүлмә. *Бухгалтерия сейфлары. Касса сейфы. Кыйммәтле кәгазьләрне сейфта саклау.* □ *Комиссиянең эшенә нормаль шартлар тудырылган: аңа аерым бүлмә бирелгән, анда телефон, документлар саклау өчен сейф бар.* Тат. ком.

СЕ'КАНС *и. мат.* Почмакның тригонометрик функциясе: турыпочмаклы өчпочмакта гипотенузаның әлеге почмакка чиктәш катетка чагыштырмасына тигез.

СЕКВЕСТР *и.* 1. *махс.* Берәр төрле милектән файдалануны өлешчә яки тулысынча тыю (власть органнары тарафыннан эшләнә). *Йорт-җиргә секвестр салу. Банктагы счетка салынган секвестрны алдыру.*

2. *мед.* Берәр төр тукыманың (гадәттә сөякнең) үлеп, сау организмнан аерылып торган өлеше, кисәге. *Сөяк секвестры. Ярадан секвестр чыгу.*

СЕКВО'ЙЯ *и. бот.* Төньяк Америкада үсә торган ылыслы гигант агач.

СЕКРЕТ *и. хәрби.* Яшерен күзәтү посты. *Секретка бару. Секретта тору.* □ *Як-якларга секретлар куеп чыккач, [командир] партизаннарны үз янына чакырды.* И. Туктар. || Шул постта торучы яки торучылар. *Бик озак вакытлар фронтларда тынлык булып торды. Кыш буена бөтен фронт буйлап вак-төяк атышлардан, дозорлар, секретлар һәм разведчикларның үзара очрашып бәрелешүләреннән башка зур сугышлар булмады.* М. Гали. *Сугышчыларның күпчелеге йоклый. --- Тик часовойлар, алдагы дозорлар, секретлар гына төннәрне йокысыз үткәрәләр.* Г. Иделле.

СЕКРЕТАРИАТ *и.* 1. Дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында: гомуми оештыру һәм җитәкчелек яки секретарьлык эшләрен үтәүче бүлек, орган. *Партия органнарының секретариаты. БМО секретариатында эшләү.*

2. *җый.* Шундый бүлектә, органда эшләүчеләр. *Секретариат исемлеге.*

СЕКРЕТАРЬ *и.* 1. Дәүләт яки җәмәгать оешмасының яисә аерым кешенең гомуми язу-сызу эшләрен башкаручы. *Авыл советында секретарь булып эшләү.* □ *Әледән-әле звонок шалтырый. Сап-сары чәчле, кызыл иренле, ялангач симез беләкләренә сипкел төшкән секретарь ханым начальникка кирәкле кешеләрне чакыра тора.* Э. Еники.

2. Җыелыш-утырышларда: беркетмә язучы. *Рәис булды, инде секретарь кирәк, кемне күрсәтәбез? — дип сорап, [Нигъмәт] мәҗлескә карады.* Г. Ибраһимов.

3. Берәр оешманың сайлап куелган җитәкчесе. *Партиянең башлангыч оешмасына секретарь булып сайлану.*

СЕКРЕТАРЬЛЫК *и.* Секретарь вазифалары һәм эше. *Колхозның башлангыч партия оешмасының ябык җыелышы булды. Хафиз партоешма секретарьлыгыннан азат ителде.* М. Хәсәнов.

СЕКРЕТЕР *и.* Язу өстәленең яки китап шкафының бер төре (язу-сызу өчен махсус кайтармалы яки шудырып чыгармалы бер тактасы һәм кәгазь-китап өчен тартмалары яисә шүрлекләре була).

СЕКРЕ'ЦИЯ *и. физиол.* Биз күзәнәкләрендә махсус сыекча эшләнү һәм бүленеп чыгу күренеше. *Эчке һәм тышкы секреция органнары. Секреция бизләре.*

СЕКСТАНТ *и. махс.* Астрономик һәм геодезик күзәтүләр вакытында почмак үлчәү коралы. *Без инде күптән ачык океанга чыктык. Җир шарының кайсы ноктасында икәнлегебезне секстант ярдәмендә кояш белән йолдызларга карап билгелибез.* Р. Мостафин.

СЕКСТЕТ *и. муз.* 1. Алты тавыш яки алты уен коралы өчен язылган әсәр.

2. Алты башкаручыдан (җырчы яки уен коралы уйнаучыдан) төзелгән ансамбль, төркем.

СЕКСТИЛЛИОН Берәмлек һәм егерме бер нуль белән күрсәтелә торган сан.

СЕКСУАЛИЗМ *и. кит.* Җенси тойгыга һәм хискә бирелүчәнлек.

СЕКСУАЛЬ *с. кит.* Җенси тойгыга яки якынлыкка мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Бурҗуаз әдәбияттагы сексуаль темалар. Бозык кешеләрнең сексуаль тормышы.*

СЕ'КТА *и.* 1. Хакимлек итүче дини оешмадан аерылып чыккан, дини догматлары һәм йолалары үзгәрәк булган төркем яки община. *Баптистлар сектасы. Сектада член булып тору.* □ *[Кайбер] секта җитәкчеләре диннәр турындагы совет законнарын турыдан-туры бозу юлына басканнар.* Тат. ком.

2. *күч. кит.* Күпчелектән, халыктан аерылып, үзләренең вак, тар ихтыяҗ-максатлары даирәсенә кереп бикләнгән кешеләр (гадәттә җәмәгать эшлеклеләре) төркеме.

СЕКТАНТ *и.* 1. Берәр дини секта члены. *Хәзер сектантларның гыйбадәт кылу өчен яшерен җыйналулары кими.* Тат. ком.

2. *күч. кит.* Күпчелектән, халыктан аерылып, үзенең вак, тар ихтыяҗ-максатлары даирәсенә кереп бикләнгән кеше (җәмәгать эшлеклесе һ. б. ш.). *Массалар белән элемтәдән башка партия үзенең көчен югалта, сектантлар оешмасына әверелә.* КПСС тарихы.

СЕКТАНТЛЫК *и.* 1. Сектант (1 мәгъ.) булу хәле.

2. *күч.* Күпчелектән аерылып, вак, тар ихтыяҗ һәм максатлар өлкәсенә кереп бикләнгәнлек (җәмәгать эшлеклеләре һ. б. ш. турында). *Массалардан аерылганлык кайвакыт Англия социал-демократларына беркадәр сектантлык характеры бирде.* В. И. Ленин.

СЕ'КТОР *и.* 1. *мат.* Яссылыкта: түгәрәкнең ике радиус һәм дуга белән чикләнгән өлеше. *Түгәрәк секторы.*

2. Берәр мәйданның радиаль сызыклар белән чикләнгән өлеше. *Стадионның көньяк секторы.* □ *Лейтенант Гобәйдуллин, берсеннән берсенә шуышып, пулемет ячейкаларын әйләнеп чыкты. Аларга яңа ату секторлары билгеләде.* Каз. утл.

3. Кайбер дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында: бүлек, бүлекчә. *Фәнни тикшеренү институтының секторлары. Тарих секторы.* □ *Утыз бишенче елның язында студиядә әдәби сектор төзелде.* М. Җәлил. *Мәсьәләләр бик мөһим һәм алар ул [чирле әнисе янына ашыгучы Госман] җитәкчелек итә торган секторга бик нык бәйләнешле булганга, [утырышны] ташлап чыгып китә алмады.* А. Шамов.

4. Дәүләт эшенең, халык хуҗалыгының берәр тармагы, өлкәсе. *Халык хуҗалыгының промышленность секторы. Сәүдә секторы.* □ *Социализм секторы белән капитализм секторларының янәшә яшәп, соңгының үзлегеннән бетүенә ышанып карау „Картайдым шул" дигән „нәни шаяру" характерындагы шигырьдә дә күренә.* Г. Нигъмәти.

СЕКУНД *и.* 1. Минутның алтмыштан бер өлешенә тигез вакыт үлчәве берәмлеге. || Бик кыска гына вакыт; бер тын. *Без рәшәткә янына килдек тә берничә генә секунд суга карап тордык.* Ф. Әмирхан. *Низаминың йөзенә бер секунд эчендә өч-дүрт төрле чырай чыкты.* М. Әмир.

2. *мат.* Почмак яки дуга үлчәү берәмлеге: градусның 1/3600-енә тигез.

СЕКУНДАНТ *и. иск.* 1. Дуэльгә чыгучының арадашчылык һәм шаһитлек хезмәтләрен үтәүче ышанычлы кешесе.

2. Бокс һәм шахмат ярышларында: катнашучылардан берсенең арадашчысы һәм ярдәмчесе.

СЕКУНДАНТЛЫК и. Секундант хезмәте һәм вазифалары.

СЕКУНДЛАП *рәв.* 1. Бер секунд чамасы (вакыт турында).

2. Һәр секунд саен; секундлар үткән саен. *Бу теләү минутлап кына түгел, секундлап арта вә көчәя бара иде.* Ф. Әмирхан. || Секундлар белән санап (вакытны исәпләү турында). *Ярышта вакытны секундлап исәпләү.*

СЕКУНДЛЫ *с.* 1. Секундлар белән генә исәпләнә торган, бик әз (кыска вакыт арасы турында).

2. Секундларны күрсәтә торган (сәгать угы турында). *Сәгатьнең секундлы угы ычкынып төшү.*

СЕКУНДЛЫК *с.* 1. Бер секунд дәвам итә торган. *Секундлык пауза.*

2. Секундлар белән генә үлчәрдәй әз һәм бик кыска вакыт эчендә, тиз генә башкарыла торган. *Секундлык эш турындагы сүзне сәгатькә сузу.*

СЕКУНДОМЕР *и.* Вакытны секундның унарлы өлешенә кадәр төгәллек белән үлчи торган корал. *Узышлы ярышларда судьяның секундомер тотып торуы.* □ *Җир өстендә секундомер белән санап торучы инптәшләр минем, ашыга төшеп, биш секунд үтүгә парашютымны ачып җибәрүемне әйтәләр.* С. Баттал.

СЕКУНДОМЕРЧЫ *и.* Спорт ярышында: секундомер белән вакыт үлчәп, билгеләп торучы.

СЕ'КЦИЯ *и.* 1. Кайбер дәүләт оешмасы, учреждение, җәмгыять һ. б. җирдә: бүлек яки бүлекчә. *Азык кибетендәге секцияләр. Язучылар союзының иҗат секцияләре. Тәнкыйтьчеләр секциясенең утырышы.* □ *Дюпов көрәшчеләр секциясендә тренировкалар башлап җибәрде.* А. Яхин. || Съезд, конгресс, конференция, киңәшмәгә һ. б. ш. катнашучыларның төрле мәсьәләләрне бүленеп тикшерү өчен төзелгән төркемнәреннән берсе. *Фәнни конференциядә докладларны секцияләргә бүленеп тыңлау.*

2. *махс.* Каралты-корылма, эре җиһаз кебек нәрсәнең өлеше, ваграк бүлемтекләрдән тора торган бүлеме, буыны, кисәге, блогы, торыгы. *Газ үткәргеч торбаның секцияләрен ялгау.* □ *— Әнә, күрәсеңме яңа баракны? Шуның беренче секциясендә уң кул якта торабыз.* А. Расих.

СЕЛЁДКА *и. сөйл. к.* сельдь.

СЕЛЕКМӘ *и. сөйл.* Ерткыч балыкны тота торган алдавыч: гадәттә вак балыкка охшатып ясалган, бер яки берничә җәпле кармак беркетелгән елтыравыклы калай; *русчасы:* блесна.

СЕЛЕ'КТОР *и.* 1. Телефон элемтәсен, технологик процессларны һ. б. ш. эшләрне идарә итүдә кулланыла торган электромагнит автоматы.

2. Шундый автомат куелган телефон аппараты (шул линиядәге барлык абонентлар белән берьюлы сөйләшергә мөмкинлек бирә). *Завод директоры селектор буенча заводның үткән көндәге эш йомгакларын игълан итте.* Соц. Тат.

СЕЛЕ'КТОРЧЫ *и.* Селекторга хезмәт күрсәтүче, шуның белән эшләүче. *Селекторчы диспетчер.*

СЕЛЕКЦИОН *с.* Селекциягә мөнәсәбәтле.

СЕЛЕКЦИОНЕР *и.* Селекция белгече, шул өлкәдә эшләүче. *Агрономнар, селекционерлар, авыл хуҗалыгы практиклары тармаклы бодайның безнең шартларда яхшы уңыш бирә торган яңа сортын чыгару өстендә эшлиләр.* Ә. Еники.

СЕЛЕ'КЦИЯ *и.* Ясалма сайланыш юлы белән үсемлекләрнең сортларын, хайваннарның нәселен яхшырту яки яңа сортлар һәм нәселләр китереп чыгару эше. *Селекция станциясе.* || Шул турыдагы фәнни теория. *Үсемлекләр селекциясе.*

СЕЛЕН *и.* Химик элемент, металлоид.

СЕЛЕНЛЫ *с.* Составында селен булган, селен катнашкан.

СЕЛЕНОГРА'ФИК *с.* Селенографиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Селенографик киңлек.* □ *Автомат станция Ай өстендә Давыллар океаны районына йомшак кына төшеп утырды. Бу урынның селенографик координаталары [билгеләнде].* Соц. Тат.

СЕЛЕНОГРА'ФИЯ *и.* Астрономиянең Айны тикшерә, өйрәнә торган тармагы.

СЕЛИ'ТРА *и. хим.* Калий, натрий, аммоний һ. б. кайбер элемент һәм матдә оксидларының тозы (шартлаучан матдәләр һәм авыл хуҗалыгы ашламалары ясауда кулланыла).

СЕЛКЕГЕЧ *и. тех.* Селкү, селкеп җилпү җайланмасы, аппараты (гадәттә берәр агрегатта, машинада). *Ашлык комбайнының селкегече.* □ *Салам селкегечләр өстендә пар төсле булып ак тузан күтәрелә.* А. Шамов.

СЕЛКЕНЕШ *и.* Селкенү хәрәкәте һәм хәле. *Яфракларның селкенеше белән хәрәкәтләндерелә торган кояш нуры түгәрәкләре күлгә төшкән җирләрне дә төрләндерәләр.* Ф. Әмирхан. [*Картның*] *күзләре кысылган. Күз карашларында һәм селкенешләрендә озак яшәгәнлек, күпне күргәнлек сизелеп тора.* М. Җәлил.

СЕЛКЕНМӘ, СЕЛКЕНМӘЛЕ *с.* Селкенеп, атынып тора торган. [*Рокыя*] *йөгереп барып селкенмәле креслога утыра да бераз селкенеп тора.* Ф. Әмирхан.

СЕЛКЕНЧӘК *с.* 1. Селкенеп, калтырап тора торган. *Бу урманнарның эчендә селкенчәк сазлыклар очрый-лар.* Г. Ибраһимов. [*Кадермәт*] *селкенчәк урындыкка килеп утыра.* Н. Исәнбәт.

2. *и. мәгъ. к.* койка [қойқа]. *Әби балык шулпасы һәм балык селкенчәге белән сыйлады.* Х. Мөҗәй.

3. *и. мәгъ. зоол.* Чыпчыксыманнар отрядыннан өстән аска селкенеп-атынып торган озынрак койрыклы кошчык; чәберчек; *русчасы:* трясогузка. *Селкенчәкләр пырхылдап тумгәктән тумгәккә сикерешәләр: җитез тегүче кайчысы кебек, озын чатлы койрыклары йөреп кенә тора.* М. Шабаев.

СЕЛКЕНҮ *ф.* **1.** Тирбәлеп, чайкалып, калтырап кыймылдау, баштагы хәлгә кимендә бер кайта торган хәрәкәт ясау. *Трактор узганда күпер селкенү. Җилгә агач башлары селкенү. Урамнан авыр машина узганда өй селкенү.* □ *Бию кызды. Идән такталары сыгылып-сыгылып килде. Стеналар селкенде. Өстәл селкенде.* Г. Гобәй. || Калтырап тирбәнү; чайкалу-атыну. *Баштарак безнең пароходчыгыбыз бераз калтыранды гына, аннан соң инде нык ук селкенә, тирбәнә башлады.* Ф. Әмирхан. *Кайдадыр якында гына снаряд төшеп ярылды. Җир селкенеп китте.* Г. Әпсәләмов.

2. Тыныч хәлдән хәрәкәткә күчеп, кыймылдап-кузгалып кую. *Селкенми басып тору.* □ *Хәйдәрнең кара бөдрәләрен җил тузгыта, матур уелган борын канатлары еш-еш селкенә иде.* Г. Бәширов.

3. Какшаган булу, какшау; нык беркетелмәү яки куба-какшый башлау сәбәпле, кузгалырга әзер, буш булу. *Шөреп селкенү. Койманың берәр тактасы селкенү. Ишек тоткасы селкенү.* □ [*Абыстайның*] *авызында аслы-өсле селкенеп торган ике казык теше генә калган иде.* М. Гали. [*Хуҗа*] *иң элек дуганы селкетеп карый. --- Камыт бавы йомшак тартылып, селкенә торган булса, --- пыр туза: болай булса, атны харап итәсез, ди.* М. Гафури.

4. *күч.* Тигезсез, дыңгырдык юлда, дыңгырдык транспортта: тирбәлеп, уңайсыз чайкалып бару. *Пароход белән Чаллыга кадәр барып, аннан соң алтмыш чакрым автобуста селкенергә кирәк* [*Зәйгә җитү өчен*] *диделәр белгән кешеләр.* А. Гыйләҗев. *Юлда селкенеп, миңгерәп беткән бораулаучылар автобустан төштеләр.* Ш. Бикчурин.

5. *күч. сөйл.* Бер тын җитез генә тырышлык, бераз актив эшчәнлек күрсәтү.— *Яшь чакларда, бала чакларны искә төшереп, җиң сызганып бер селкенеп алу ниятең дә бар, аннары авылдашлар да синдә ничек игенче каны уйнавын бер күрсеннәр әле!* Р. Төхфәтуллин. || Талчыгу, хәлсезләнү яки ирену сәбәпле, җиңелчә генә эшләү (гадәттә физик хезмәтне). [*Шәйхаттар карт:*] *Заманына күрә алай чуттан чыгарып ук ташларлык түгел әле мин, әнем, селкенә алам ич әле.* Г. Гобәй. || *гадәттә ирон.* Эшләгән булып күренү өчен генә тырышу.

СЕЛКЕТҮ *ф.* **1.** Төрле якка атындырып, кыймылдатып яки бүтәнчә хәрәкәтләндерү. *Суырып чыгару өчен казыкны селкетү.* □ *Куян, урыныннан торып, озын колакларын селкетте.* Дәрдмәнд. [*Зөләйха:*] *Менә бу алманы алыйм дигән идем дә, төшми.* [*Зифа:*] *Агачын ныграк селкетсәң, төшәр.* М. Фәйзи. || Тирбәтү. *Бишек селкетү.*

2. Калтыратү, тетрәтү, дерелдәтү. *Шартлау тавышы бөтен дөньяны селкетеп җибәрде.* Ш. Усманов. *Ябык ындыр эчендә, тирә-яктагы бөтен әйберләрне селкетеп, сугу машинасы үкерә, җилгәргеч зырылдый, кешеләр кайнаша.* Г. Әпсәләмов. *Күк күкрәве җирне селкетә.* Ф. Кәрим.

3. Сикертеп-калтыратып яки чайкалдырып борчу (дыңгырдык юл һәм транспорт турында). *Самолетның селкетүенә күнел болгана башлау. Дыңгырдык юлның селкетүенә түзә алмыйча, арба яныннан җәяүләп бару.* || з-сыз. Транспортның яки юлның сикертеп-калтыратып яисә чайкалдырып тирбәтүе-борчуы турында. *Җил көнне пароходта барганда бик селкетү.* □ [*Әтисе — ат башына утырып ат тотып барырга теләүче бәләкәй улына:*] *Син булдыра алмассың, улым. Анда бик селкетә: я ялгыш ат аягы астына егылып төшәрсең.* М. Гали.

СЕЛКҮ *ф.* **1.** Тузанын, чүбен һ. б. ш. кагып төшерү өчен кискен хәрәкәт белән болгау, селтәү, җилпү. *Карын кагу өчен бүрекне селкү. Келәмне тышка алып чыгып селкеп керү.* □ [*Малай*], *урыныннан кузгалып, төренеп яткан бишмәтен селкеп, ябышкан яфракларны төшерде.* Ф. Кәрим. || Кискен болгау, селтәү яки җилпү хәрәкәте ясап, әйбердәге тузан, чүпне һ. б. кагып төшерү, очыру. *Фатыйманың да йокысы килә, ләкин башлаган тәрәшлесен бетерәсе килә аның. Менә ул эрләп бетерә дә альяпкычындагы чүпне идәнгә селки.* И. Гази. [*Бомба төшүдән соң*] *Җамали аягына басып, өстеннән балчык кисәкләрен селкеп, як-ягына караганда үзенең алдында яңа гына казылган зур бер чокыр күрде.* М. Гали. || Авызын, өстен түбән караткан хәлдә кискен болгап, селтәп яки җилпеп, эчендәге әйберен бушату (капчык, савытны һ. б.). *Кесәне әйләндереп селкү. Балыгын бушатканда сөкәне ярга алып селкү.* □ [*Тоз ташуда эшләгән Хәлим*] *капчыгын баржа авызына селекте дә йөгерә-йөгерә кайтырга чыкты.* И. Гази.

2. Канатны: очу өчен хәрәкәтләндерү, җилпү. *Якыннан гына очып үткән юеш карганың авыр гына селеккән канат тавышы ишетелеп кала.* Э. Еники.

3. Болгау, төрле якка хәрәкәтләндерү. *Сыерлар, койрыкларын селкеп, башларын бер-берсе өстенә куеп, өелешеп тораллар.* Г. Әпсәләмов. || Изәү, берәр ишарә хәрәкәте ясау. *Бармак селкү. Баш селкү. Йодрык селкү.* □ *Яр буендагы хатын-кыз, картколары безне яулык болгап, бүрек селкеп озатып калды.* Ә. Айдар. [*Командир*], *мылтыкларын төзәп торган берничә дистә кешегә карап, кулындагы кылычын селкеп, атарга ишарә итте.* М. Гафури.

4. Нык кыймылдату, җилтерәтү, селкетү. *Ул иптәшләрен, кайсын төртеп, кайсын селкеп, уятырга тотынды:— Тор әле, тор!* Г. Гобәй. *Разия, кинәт башын калкытып, бөдрәләрен селкеп куя.* И. Гази.

5. *к.* селкетү (3 мәгъ.). *Шәп барабыз. Давыл гына эшне бозып ташламасын. Әле күптән түгел генә --- „Байкал"ны* [*баржаны*] *бик нык селкегән.* С. Сабиров.

СЕЛТЕ 1. *и.* Берәр тоз белән кислота кушылуыннан барлыкка килгән зәһәр химик матдә. *Барий селтесе.* □ *Селте тәэсирендә урыны-урыны белән тиренең йоны коелучан була.* М. Максуд.

2. Агач көле салып кайнатылган эремә (кер юуга тотыла). *Кер юарга селте кайнату.* □ *Зөһрә апа, --- самовар кайнатып, көлдән селте ясап, хәлфә абыйның бөтен керләрен юды.* Г. Гобәй.

СЕЛТЕЛЕ *с.* Селте салынган, катнаштырылган. *Селтеле су.* □ *Тиреләрне юу һәм майсызландыруда хәзергә кадәр селтеле сода һәм сабын кулланыла иде.* М. Максуд.

СЕЛТЕЛӘНҮ *ф.* Селтелегә әйләнү (су һ. б. ш. турында). || Селтегә әйләнү (көл һ. б. ш. турында). *Кайбер агач көленең начар селтеләнүе.*

СЕЛТЕЛӘҮ *ф.* **1.** Селтеле итү, селте катнаштыру.

2. Селте белән эшкәртү. *Керне селтеләп юу.*

СЕЛТӘНЕШ *и.* **1.** Селтәнү (1, 2 мәгъ.) хәрәкәте. *Көчле селтәнеш белән бәрү.* || *күч.* Зурдан кубып эшләнгән һәм дәгъвалы-һавалы тәнкыйть, һөҗүм. [*Шагыйрь ижатының беренче елларын танымаска өндәү*] — *гүзәл башлангыч чорны бер селтәнүдә сызып ташлау дигән сүз. Кыюлыгы белән бер үк дәрәҗәдә мәгънәсез селтәнеш!* М. Максуд.

2. *күч. сир.* Селтәнү (3 мәгъ.) эше; омтылыш.

СЕЛТӘНҮ *ф.* **1.** Селтәү хәрәкәте ясау (күл яки корал белән). *Печәнне киң селтәнеп чабу. Чабагач белән көлтә сукканда салмаграк селтәнергә тырышу. Спиннингны селтәнебрәк ыргыту. Балтаны селтәнеп*

чабу. Чүкечне селтәнмичә генә сугу. Авыр тукмак белән селтәнүе кыен булу. □ *Бикмүш бабай [ишкәк белән] бер-ике селтәнүгә зәңгәр маякка килеп җитте.* Г. Гобәй.

2. Сугарга, бәрергә кизәнү. *Таяк белән селтәнү.* □ *Чыбыркы белән малайларга берәм-берәм селтәнә башладым.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Һөҗүм итәргә маташу яки итеп карау. *Илебезгә селтәнгән агрессорның теше коелу.* || *күч.* Зурдан кубып тәнкыйтьләргә маташу. *Классикларга селтәнү.*

3. *күч.* Әһәмиятле, кыен бер эш эшләргә, кыйммәтле берәр нәрсәгә ирешергә омтылу. *Автомобильгә селтәнгәндә ваграк ихтыяҗларны онытып тору.*

СЕЛТӘҮ *ф.* **1.** Болгау, селкү. *Таяк селтәү. Этләрнең койрык селтәве.* □ *Команда сүзләренә буйсынып, кулларын киң селтәп бара [Шәрифҗан].* И. Гази. *[Балыклар] әле анда, әле монда су өстенә калкып чыгалар да, койрыкларын селтәп, чумып китәләр.* С. Сабиров. || Кизәнеп болгау. *Камчы селтәү.* □ *Туры юлдан бардым ат уйнатып, --- Уңга-сулга селтәп кылычымны.* М. Гафури. *Кан тамырларым тулып таша, чалгы бер селтәүдә дөньяны кырып төшерердәй бер гайрәт белән ала иде.* Г. Ибраһимов. || Изәү (кулны һ. б.). *[Хәмдия] ишектән башын тыгып Бакыйга кул селти.* М. Фәйзи. *Артыма борылдым да Госманга кул селтәп кычкырдым.* Ф. Хөсни. || Җилпеп селкү, кагу (канатны һ. б.). *[Акчарлаклар] ак канатларын селтәп-селтәп, бер югары, бер түбән очып --- кычкырыналар.* Ш. Камал.

2. Ыргыту, чөю. *[Шаһтимер] ташны көтүгә таба селти.* М. Фәйзи. *Күз ачып йомганчы малайлар [көрәшүчеләр] бер-берсен селтиләр дә ыргыталар, селтиләр дә ыргыталар. Бер егучыга унлабы сикереп тора.* Э. Еники.

3. Сугу (гадәттә кизәнеп, селтәнеп). *Әнисе, ачуланып, чыбык алды да: — Кит әле, каймакны пычратма син! — дип, песигә берне селтәде.* Д. Аппакова. — *Ачу белән ярсып, Госманның битенә камчым белән селтәп җибәрдем.* Ф. Хөсни. || Сугып егу; кыйнау. *Көтелмәгән җирдән әптелбәр атылып чыкты да Габдулланы үчеклэп торучы малайлар өстенә ташланды, аларны уңлы-суллы селтәп ташлады.* Э. Фәйзи.

4. *күч. сөйл.* Кулга төшерү, алу. *Егет кенә түгел, карчыга ул безнең кияү. Шулай булганга күрә илдә бер булган Маһруйны селтәде дә.* М. Фәйзи. *Канатларын җитез селки ул [акчарлак], Вак хамсаны [балыкны] бик тиз селти ул.* К. Нәҗми. || Урлау. — *Малай чакны шулай берәүдән каеш чыбыркы селтәп кайттым.* А. Расих.

СЕЛЬДЕРЕЙ *и. бот.* Тамыры һәм яфрагы аш тәмләткеч итеп файдаланыла торган ике еллык яшелчә үсемлек.

СЕЛЬДЬ *и. зоол.* Күбесенчә диңгездә яши торган, әре булмаган, төрлечә әзерләп ашау өчен аулана торган балык.

СЕЛЬПО *и.* Авыл җирендә: сатып алучылар җәмгыяте; *русчасы:* сельское потребительское общество. *Сельпо кибете.* □ *— Сельпога балалар киеме кайтасы дигәннәр иде.* Г. Бәширов.

СЕЛӘГӘЙ *и.* **1.** Авыз куышлыгында бүленеп чыга һәм азыкны юешләп-чылатып эшкәртү өчен хезмәт итә торган, сузылыбрак торучан сыекча (кеше авызы эчендәгесе „төкерек“ тә диелә). *Селәгәйне (яки төкерекне) йоту. Селәгәе ага торган бала.* □ *Тәмле азыкны күрү белән авыздагы селагәй бизләре сыекча бүлеп чыгара башлый. Ул сыекча азыкны эшкәртергә ярдәм итә.* Ялкын. *Хайван авызыннан аш кайнату юлларына өзлексез рәвештә селәгәй агып тора.* А. Расих.

2. *с. мәгъ. сөйл.* Селәгәе авызыннан еш (күп) агып тора торган. *Селәгәй бала.* || *гади с.* Булдыксыз, җебегән, бик ихтыярсыз кешене хурлау сүзе. — *Кулыннан бер тиенлек эш килми, борынын да юньләп җыештыра алмый, селәгәй! Ә үзе кызлар белән йөргән була!* Г. Камал. *Иптәшләрен саткан селәгәйне, белә-сеңме, нишләтәләр!..* Б. Камалов.

СЕЛӘГӘЙЛӘНҮ *ф.* Селәгәйгә (2 мәгъ.) әйләнү.

СЕЛӘҮЧӘН *и. зоол.* **1.** Сөяксез, нечкә йомшак тәнле, шуышып хәрәкәтләнүче озынча корт; *русчасы:* дождевой червь. *Кармакларны, селәүчәннәр, икмәкләр, йомыркалар, шырпыларны алабыз да --- елгага барабыз.* Г. Ибраһимов. *Авызына кызыл селәүчәннәр капкан кара канатлы сыерчык басу яклап кайтып килде дә колга башындагы ояның түбәсенә кунды.* Г. Галиев.

2. Кешенең һәм умырткалы хайваннарның эчәклегендә яши торган паразит корт; *русчасы:* аскарида. *Эчең авырта торган була, үзең ябыгасың. Селәүчән авыруы була.* Г. Бәширов.

3. Кеше, хайван яки үсемлек организмында (эчке органнарда, тукымаларда) яшәүче паразит корт; *русчасы:* глиста.

СЕЛӘҮСЕН *и. зоол.* Күбесенчә урманда яши торган, соргылт-җирән яки тимгел-тимгел куе йомшак йоннлы, мәчеләр төреннән булган ерткыч; *русчасы:* рысь. *Мондый караңгы тау ярыкларында гадәттә көндезләрен төрле тиеннәр яшереиеп ята. Нәрсәләр генә булмый анда: барслар, шакаллар, селәүсеннәр.* М. Госманов. — *Мин тере селәүсенне дә, боланны да, кабанны да тота алам.* А. Гыйләҗев.

СЕМА'НТИК *с. лингв.* Семантикага мөнәсәбәтле. *Сүзнең семантик үзенчәлекләре. Семантик анализ. Семантик категория.*

СЕМА'НТИКА *и. лингв.* **1.** Сүз, идиома, сүзтезмә, җөмлә һ. б. ш. категорияләрдә: мәгънә. *Сүзләрнең яки идиомаларның семантикасы үзгәрү.*

2. *к.* семасиология.

СЕМАСИОЛО'ГИК *с. лингв.* Семасиологиягә мөнәсәбәтле.

СЕМАСИОЛО'ГИЯ *и.* Тел фәнендә: сүзләр, идиомалар, төрле сүзтезмәләр һәм җөмләләрнең мәгънәләрен тикшерүгә багышланган тармак.

СЕМАФОР *и.* Юлларда: багана, колга һ. б. ш. башына куелган сигнал җайланмасы. *Семафор ачык булмау. Паровозның семафорга якынлашканда гудок кычкыртуы.* □ *Поезд семафорны узу белән, Яйсанның күренеше, исеме хәтердән чыга.* Ш. Усманов.

СЕМЕСТР *и.* Югары һәм махсус уку йортларында: уку елының бер яртысы.

СЕМИНАР *и.* **1.** Студентлар группасының практик эш дәресе.

2. Берәр махсус темага багышлап группа белән үткәрелә торган белем күтәрү занятиесе, түгәрәк утырышы һ. б. ш. *Агитаторлар семинары. Пропагандистлар семинары. Терлекчеләр семинары.* □ *Республика халык иҗаты йортында --- драматурглар семинары булды.* Соц. Тат.

СЕМИНАРИСТ *и.* Семинария укучысы. *Арада чалма, җилән кигән татар муллалары, каракүл бүреклe, казаки, читек-кәвешле төрле татар сәүдәгәрләре, студент, семинарист киемендәге казакъ егетләре [бар иде].* Г. Ибраһимов.

СЕМИНА'РИЯ *и.* **1.** Элекке Россиядә: русларның урта педагогик уку йорты. *Иван Андреевич --- ундүртенче елны укытучылар семинариясе тәмамлаган, әмма укытырга туры килмәгән, сугышка алынган.* Каз. утл.

2. Рус руханиларын хәзерли торган урта уку йорты. *[Купец Голиков] духовный семинариядә үз акчасына*

ничә кешене укытып поп ясаган, миссионерлык фондына санап бетергесез ярдәмнәр күрсәткән. К. Нәҗми.

СЕМИО'ТИК, СЕМИОЛО'ГИК *с.* Семиотикага мөнәсәбәтле, шуңа караган.

СЕМИО'ТИКА, СЕМИОЛО'ГИЯ *и.* Шартлы яки шартсыз хәбәр-информация чыганагы-иясе булган, нинди дә булса бер мәгънә белдергән билгеләр, тамгалар, сигналлар, әзләр (шул исәптән аларның системалары) турындагы фән. *Кайберәүләрнең тел фәнен дә семиотика тармагы дип каравы.*

СЕМИТ *и.* Алгы Азиянең, Төньяк һәм Көнчыгыш Африканың бер өлешен биләп яшәгән яки яшәүче (борынгы вавилон, ассирияле, финикияле, яһүд һ. б.; хәзерге гарәп, сирияле, еврей, абиссинияле) халыклар вәкиле.

СЕМИТО'ЛОГ *и.* Семитология белгече.

СЕМИТОЛО'ГИЯ *и.* Семит телләрен һәм культурасын тикшерә торган фәннәр.

СЕМЬЯ *и.* **1.** Ата-ана белән балаларның, кардәшләрнең һәм бүтән якын кешеләрнең бергә тәрбияләнеп яшәүче төркеме. *Сөекле шагыйребез Тукай үзенең бер семьядан икенче семьяга, бер ана кулыннан икенче ана кулына күчеп йөргән сабыйлык елларында бераз вакыт Яңа бистәдә яшәгән.* М. Максуд. *Ун көн элек кенә өйләнешкән яшь семья бу. Яшь ир, яшь хатын.* Ш. Маннур. || *махс.* Җәмгыятьнең шундый төркемнән гыйбарәт иң кечкенә берләшмәсе, оешмасы. *Семья кору. Хезмәтчел семья. Эшче-крестьян семьясы. Буржуаз семья.* □ *Шагыйрь кайбер мәсьәләләрдә „сул" фразага бирелеп куя. Ул көнкүреш мәсьәләләренә нык игътибар итә. --- Ләкин сыйнфый этиканы яклыйм дип, гомумән семьяга каршы күсәк күтәрү дә очрап куя.* М. Максуд. *Революциягә кадәр булган иске тормыштагы семьяда каенеш, бигрәк килен белән каенана мәсьәләсе зур проблема булып торадыр иде.* М. Гали. || Шундый төркемдә: баш кешедән (ата яки анадан һ. б.) кала барлык бүтән тәрбияләнүчеләр. *Фронтовик семьясы.* □ *Арбада, ишле семьясы белән бергә утырып, --- Нигъмәтҗан карт [бара].* К. Нәҗми. || Ата белән ана карамагындагы барлык тәрбияләнүчеләр.

2. *күч. кит.* Уртак эш, уртак максат хакына берләшеп дус яшәүче кешеләр төркеме; тату коллектив. *Дус халыклар семьясында Республикам тиң минем.* Ш. Маннур. *Хәзер мин — таза тормышлы колхоз семьясының бер члены.* А. Шамов. *Төрлесе төрле пароходлардан, ФЗӨ мәктәпләреннән килгән һәм әле бер-берсен юньләп танып та өлгермәгән команда членнарын бер семья итеп оештырыргa, аларның күңелләрендә теплоход өчен горурлык тойгысы уятырга, көчләрен алда торган бурычларны үтәүгә туплларга кирәк иде.* С. Сабиров.

3. Бер ата-анадан булып, бер ояда үсүче яки яшәүче хайваннар төркеме. *Бал кортлары тырышып бал җыялар һәм, ишләре артык күбәеп умарталарына сыймый башлаганлыктан, яшь семьяларны үзләреннән аерып башка чыгаралар.* Ф. Хөсни.

4. *лингв.* Кардәш телләрнең иң зур төркеме. *Алтай телләре семьясына керүче төрки телләр. Һинд-Европа телләре семьясы.*

СЕМЬЯЛЫ *с.* Семьясы (1 мәгъ.) булган, семья белән яшәүче. *Мин семьялы кеше цдем инде. Улыбыз Феликс матур булып үсеп килә иде.* М. Максуд. *Себер рудникларының берсендә семьялылар барагында аларның бердәнбер балалары Гали туган.* Г. Әпсәләмов.

СЕМЬЯЛЫК *и.* Үсемлек һәм хайваннар дөньясында: төзелешләре охшаш һәм чыгышлары якын берничә төрне берләштергән төркем. *Класслар тагын да ваграк төркемнәргә — семьялыкларга бүленәләр. Семьялыкка бер-берсенә охшаган үсемлекләр берләштерелә.* Ботаника.

СЕМЬЯСЫЗ *с.* Семьясы булмаган, өйләнмәгән яки кияүгә чыкмаган. *Гали үз өенең болдырына менеп басты. Аның, семьясыз буйдак бер егетнең, бер үзенә бер өе бар.* К. Басыйров.

СЕМЬЯЧЫЛ *с.* Семья яратучан, аны кайтыртучан; семья җанлы. *Менә бер шигырь китабы. Укып карыйм, анда бер куянны бик семьячыл итеп күрсәткән: балалары да үзе кебек бик акыллы. Гел бишкә генә укыйлар.* Н. Исәнбәт.

СЕМЬЯЧЫЛЫК *и.* Эштә, коллективта бергә җыелган туганнар яки кардәшләр төркеменең, гомуми эшкә зыян китереп, үз максатын өстен куюы. [*Сөләйман:*] *Мин синең янга, кияү, кеше турында сөйләшергә дип кергән идем. Ярый торгандыр бит? Бу — завод йомышы түгел бугай. Моның өчен семьячылыкта да гаепләмәсләр.* Г. Әпсәләмов.

СЕНАТ *и.* **1.** Борынгы Римда: иң югары дәүләт органнарының берсе.

2. Элекке Россиядә: югары хөкем-суд инстанциясе сыйфатында шикаятьләрне карый торган һәм дәүләт аппаратына күзәтчелек итә торган хөкүмәт органы.

3. Күп кенә дәүләтләрдә: парламентның (мәсәлән, АКШ конгрессының) югары палатасы.

4. Кайбер илләрдә: югары муниципаль орган, университет советы һ. б. ш.

СЕНА'ТОР *и.* Сенат (1—3 мәгъ.) члены. *Америка сенаторлары, илләренә кайткач: Советлар Кушма Штатларны гидростанцияләр төзү өлкәсендә дә узып киткәннәр, дип әйтергә мәҗбүр булдылар.* М. Хөсәен.

СЕНА'ТОРЛЫК *и.* Сенатор вазифалары һәм хезмәте.

СЕНСАЦИОН *с. к.* сенсацияле.

СЕНСА'ЦИЯ *и. кит.* **1.** Берәр көтелмәгән вакыйга яки хәбәр нәтиҗәсендә туган гадәттән тыш көчле тәэсир, аеруча дулкынландыргыч хәл. *Көчле сенсация.* □ [*Рәхимнең фәнни тикшеренүен ошатмаучы доцент:*] *Ул лаборант сенсация ясамакчы була.* А. Расих. *Революциядән элек бер татар кызы Бельгиягә барып чыкса, бу таштан дөя туу шикелле үк могҗиза саналыр иде, искиткеч зур бер сенсация кубар иде.* М. Максуд.

2. Бик дулкынландыргыч хәлгә, тетрәткеч тәэсиргә сәбәп булган гадәттән тыш вакыйга яки хәбәр, яңалык. *Газета сенсациясе.* □ *— Нинди сенсация! — диде Саматов, укып бетергәч.— Минемчә, бу мәкаләне бөтен газеталар күчереп басарлар.* Г. Әпсәләмов.

СЕНСА'ЦИЯЛЕ *с. кит.* Сенсация ясый торган. *Сенсацияле хәбәр. Сенсацияле яңалык. Сенсацияле матбугат конференциясе.* □ *Әбүзәр абзый сенсацияле газета шау-шуларын яратып бетерми.* Г. Әпсәләмов.

СЕНСУАЛИЗМ *и.* Философиядә: тойгылар — танып белүнең бердәнбер нигезе һәм чыганагы дип таный торган юнәлеш.

СЕНСУАЛИСТ *и.* Сенсуализм тарафдары.

СЕНСУАЛЬ *с. кит.* Тойгыларга, субъектив хисләргә нигезләнгән.

СЕНТЕ'НЦИЯ *и. кит.* Үгет-нәсыйхәтле афористик җөмлә, тәгъбир.

СЕНТИМЕНТАЛИЗМ *и.* **1.** Кешенең рухи дөньясын, мохитен, тормыш шартларын идеаллаштырып һәм шул ук вакытта хискә артык бирелеп сурәтләүгә нигезләнгән әдәби агым (XVIII гасырлардагы Европада). *Бераз мистика һәм бераз сентиментализмга өлеш биргән бу романның төп герое Зыя мәхдүм — музыка колы, матурлык бәндәсе.* М. Максуд.

2. *к.* сентиментальлек. [*Сәлимов*], *Нәфисә килеп керүгә, мәҗлеснең яме китте дип уйлады. --- Колагына якынрак килеп, Хәбипкә әйтте: — дидә китәбез,*

монда хәзер сентиментализм башланыр,— диде. Г. Ибраһимов.

СЕНТИМЕНТАЛИСТ *и.* **1.** Әдәбиятта: сентиментализм тарафдары, вәкиле.

2. *кит.* Сентиментальлеккә, төче хисләргә бирелүчән кеше. [*Музыка тәэсиреннән*] *Каратагинның күз төпләрендә яшь тамчылары ялтырап киткәндәй булды.— Николай Сергеевич, Сез сентименталист...— диде Катя.* И. Гази.

СЕНТИМЕНТАЛЬ *с. кит.* **1.** Сентиментализмга нигезләнгән, шуның рухы белән сугарылган (әдәби юнәлеш, әсәр һ. б. турында). || Фикер эчтәлеге аз яки әһәмиятсез булып, вак, нечкә хисләр белән нык сугарылган, артык төче. *Сентименталь җыр. Сентименталь роман.*

2. Сентиментальлеккә, нечкә хисләргә тиз бирелүчән. *Сентименталь кеше.* □ *Язучы булу өчен тәэсиргә тиз бирелүчән сентименталь күңел генә һич җитми.* Ф. Хөсни.

СЕНТИМЕНТАЛЬЛЕК *и. кит.* Нечкә хисләргә бирелүчәнлек; мөгамәләдә артык ягымлылык, төче мәлаемлык. [*Батырлар*] *алдында баш ию төчелек тә, сентименталь лек тә түгел, бу бары тик аларга тиңсез батырлыклары өчен чиксез рәхмәтебез генә.* Г. Әпсәләмов.

СЕНТЯБРЬ *и.* Календарь елының тугызынчы, августтан соң килә торган утыз көнлек ае.

СЕНЬОР *и.* **1.** Көнбатыш Европада: җир биләп, шул җирдә чикләнмәгән власть иясе булган феодал.

2. Испаниядә: әфәнде.

СЕПАРАТ I *и.* Сөт аерту аппараты. *Иртәгесен мин фермага килгәндә, Гөлнар җаный сыерларны савып бетергән, сөтне сепаратта аерткан, сепаратны юып йөри иде.* Ә. Айдар. *Сөтне сепараттан аерганда, өсте алынган сөт кала.* А. Расих. [*Былбыл — Фәридәгә:*] *Сөтеңне бир, үземнеке белән бер уңайдан сепаратка алып барыйм.* Ю. Әмипов.

◇ **Сепарат сөте** — сепаратта аерткан, сыек сөт.

СЕПАРАТ II *с. кит. полит.* Килешүне бозып, гомуми интересларга каршы килеп һ. б. ш. рәвештә бүтәннәрдән аерылып, аерым эшләнә торган. *Сепарат килешү. Сепарат сөйләшүләр алып бару. Сепарат киңәшмә.* □ *Германия шулай ук революциянең тирәнәюе Россиядә буржуаз хөкүмәтне бетерүгә китерә һәм шуның белән бөтен дөньяда, шул исәптән Германиянең үзендә дә революцион хәрәкәтне көчәйтер дип куркудан* [*Россия белән*] *сепарат солых төзергә тырыша иде.* КПСС тарихы.

СЕПАРАТИВ *с. кит.* Сепаратизм белән сугарылган. *Сепаратив чыгышлар. Сепаратив фикерләр.*

СЕПАРАТИЗМ *и. кит. полит.* Аерылып, бүленеп чыгуга, аерымлануга омтылыш. *Сепаратизм тарафдары. Сепаратизм идеяләре.* □ *Марксизмның Россиядәге төрле вәкилләре арасында еврейләр, яки дөресрәге, аларның бер өлеше, бундчылар дигәннәре, сепаратизм, ягъни аерылу яки* [*бөтеннән*] *аерымлану политикасы алып баралар.* В. И. Ленин.

СЕПАРАТИСТ *и. кит. полит.* Сепаратизм тарафдары. *Сепаратистлар хәрәкәте.* □ *„Правда“ бундчыларның сепаратистлар икәнлеген исбат итте.* В. И. Ленин.

СЕПАРАТЧЫ *и.* **1.** Сепаратны карап-төзәтеп торучы.

2. Ферма, май заводы кебек урыннарда: сепаратта эшләүче, сөт аертучы эшче.

СЕ'ПСИС *и. мед.* Авыру барлыкка китерүче микробларның канга кереп таралуы нәтиҗәсендә организмның гомуми агулану күренеше, хәле. *Сезнең организмыгыз бик таза, каныгыз да яхшы. Медикаментлар булмауга, канлы пычрак бинтлар белән бәйләүгә дә карамастан, Сезнең яраларыгыз төзәлеп килә. Монда* [*концлагерьда*] *сепсистан үлгән күпме кешене күмдек без!* Каз. утл.

СЕПТЕТ *и.* **1.** Җиде башкаручыдан (җырчыдан яки уйнаучыдан) төзелгән музыкаль ансамбль, төркем.

2. Мөстәкыйль партияле җиде уен коралы яки җиде тавыш өчен язылган музыкаль әсәр.

СЕ'ПТИК *с.* Сепсиска мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Септик ангина.*

СЕР *и.* **1.** Әлегә ачылмаган, танып беленмәгән үзлек, сыйфат һ. б. ш. *Фән бик хикмәтле нәрсә бит ул, күп серләрне ачып бирә белә.* Ә. Еники. *Мәктәп миңа урта белем бирде, Машиналар серен аңладым.* С. Урайский. *Бригадир кыз орлыкларның Ачкан яңа серләрен.* М. Җәлил.

2. Кешегә белдерергә ярамаган, яшерен мәгълүмат һ. б. ш.— *Нәрсәдән илһам алдыгыз? Ул кадәресе сер түгелдер бит?* Г. Бәширов. [*Гөлчирә:*] *Берәүгә дә әйтмәскә дип сүз бирсәң, үзеңә бер сер сөйлим.* [*Зәмзәмбану:*] *Юк, юк, аллам сакласын, миннән сер чыгамы соң!* Т. Гыйззәт.

3. *тарт. форм.* Берәр нәрсәнең төп эчтәлеге, асылы, әһәмияте. *Гөлсинә башлаган хәрәкәтнең дә серенә төшендем.* Р. Ишморат. *Ничә ел инде шул станокта эшлим, ләкин серләренә һаман төшенеп беткән юк әле.* К. Латыйпов. || Ачыкланмаган, билгесез сәбәп. *Уңышның сере. Озак яшәүнең серенә төшенү.* □ *Аның ябыклыгының һәм аз гына сәбәп белән һуштан язарлык мәртәбәдә хәлсезлегенең дә бөтен сере шунда.* Г. Ибраһимов. *Бу чаклы юмартлыкның бер сере дә бардыр инде. Анысын да әйтеп бирегез, Хажи әфәнде.* Н. Исәнбәт.

◇ **Сер бирмәү** — хәлнең авыр икәнен сиздермәү; сынатмау.— *Егетләр, бу юлы да сынатмагыз, серне бирмәгез.* Г. Минский. *Дошманыннан җиңелмәс, сер бирмәс өчен, Иске авыл сынап карый барлык көчен.* М. Гафури. **Сер килешү** — караш, теләк, зәвык һ. б. ш. ярашу, бердәй яки якын булу; дус булу. *Аларның икесенең бер-берсе белән серләре бик килешә.* Г. Камал. **Сер сынатмау** — *к.* сер бирмәү. *Шәйдуллин сер сынатмас өчен ясалма тәкәбберлек белән иңбашларын җыерган булды.* Ә. Еники.

СЕРБ *и.* Югославия составындагы Сербия республикасының төп халкы вәкиле (көньяк славян). *Бу рота да башкорт, үзбәк, казакъ, чех, румын, серб, поляк шикелле --- халыкларны эченә алган иде.* Ш. Усманов.

СЕ'РБИЯЛЕ *и. к.* серб. || Сербия кешесе.

СЕРВАНТ *и.* Савыт-саба, табын кирәк-яраклары һ. б. ш. саклый торган тәбәнәгрәк һәм киңчә, затлы шкаф, буфет.

СЕРВИЗ *и.* Билгеле бер сандагы кешелек табынга исәпләп һәм сәнгатьчә бер төрле стильдә эшләнгән (гадәттә затлы) савыт-саба комплекты. *Аш сервизы. Чәй сервизы. Кофе сервизы.* □ [*Кайберәүләрнең*] *патша бүләкләрен хәтерләтерлек аллы-гөлле сервизларыннан яки велюрдан да капроннан, нейлоннан да перлоннан беткән кием-салымнарыннан мещанлык исе аңкый.* М. Әмир.

СЕРДӘШ *и.* Серне уртаклашучы дус. *Китаплар — сердәшем һәм юлдашым.* М. Гафури. *Бану белән алар яшьтән үк бергә уйнап үскәннәр һәм моннан берничә ел элек сердәш тә булганнар иде.* А. Шамов.— *Кайчан гына карама, сез һаман бергә. Бик сердәшләр, ахры, үзегез.* Г. Насрый.

СЕРДӘШЛЕК *и.* Сердәш булу хәле; якын дуслык. *Бу — „мин сез нәяннарны беләм бит“ дигән сыман хәйләкәр, шуның белән бергә дусларча сердәшлекне*

белгертә торган караш иде. Ә. Фәйзи. *Соңгы елларда, иҗаттагы дуслыктан тыш, чын күңелдән булган шәхси дуслык һәм сердәшлек белән бәйләнгән дустыңны — мине бу карар аеруча шатландырды.* М. Җәлил.

СЕРДӘШЧЕ *и. к.* сердәш. *Мәрьям [Шакирга] дус иде шул, сердәшче, якын киңәшче иде.* Ә. Еники. *Әле кайчан гына кара дошман булып күренгән Гайния хәзер инде, ире үлгәннән соң, аның [Маһибәдәрнең] иң якын дусты, сердәшчесе булыр кебек тоела.* Ф. Хөсни.

СЕРЕНА'ДА *и.* 1. *әд.* Көнбатыш Европада: берәүне (гадәттә сөйгән кызны) сәламләп җырлана торган хөрмәтләү, мактау җыры. *[Гашыйк егет белән кызны күзәтүче икенче кыз:] — Әбәү, кулында мандолинасы да бар: серенада җырларга хәзерләнәме әллә югыйсәм?* Г. Газиз.

2. *муз.* Лирик эчтәлекле әсәрнең бер төре.

СЕРЖАНТ *и.* Армиядә һәм милициядә: кече команда составы вәкилләренә бирелә торган исем, дәрәҗә. *Екатерина Павловна Газинурны сержант исеме белән тәбрикләде, киләчәктә сине офицер итеп күрергә насыйп булсын, диде.* Г. Әпсәләмов. || Шул исемне алган кеше.— *Төркемне сержант Ибраһимовка тапшырдым.* Ә. Айдар.

СЕРЖАНТЛЫК *и.* Сержант исеме, дәрәҗәсе.— *Белемем зур түгел, сержантлыктан ары күтәрелә алмадым.* Г. Гобәй. || Сержант вазифалары һәм хезмәте.

СЕ'РИЯ *и.* 1. Бер үк үрнәк буенча ясала, эшләнә торган нәрсәләр төркеме, төре. *Балаларда эшчеләр сыйныфының һәм партиянең көрәше һәм төзелеше белән кызыксыну тудырырлык китаплар булдырырга, аерым алганда пионерлар өчен китаплар сериясе булдырырга [кирәк].* Ф. Кәрим.

2. Кыйммәтле кәгазьләрнең (акчаларның, облигацияләрнең һ. б.) бер үк цифрлар яки хәрефләр белән билгеләнгән төркеме яки төре. *Лотереяның серия номеры.*

3. Зур кинофильмның бер сеанс дәвамында күрсәтелә торган бер кисәге, өлеше. *Киноның ике сериясен бер уңайдан карау.*

СЕ'РИЯЛЕ *с.* Бер серия (1 мәгъ.) буенча эшләнгән. *Серияле станоклар.*

СЕРКӘ I *и. бот.* Орлыклы үсемлек серкәчендә җитлегеп тарала торган төкчәләрнең берсе, аталык күзәнәге; *русчасы:* пыльца. *Рәшә уйный нурда калтыранып, Арыш кырда серкә очыра.* Ш. Мөдәррис. *Каенсарда әле арышлар яңа серкәдә утыра торгандыр, ә биредә инде тиздән уракка төшәрләр.* Р. Төхфәтуллин.

◇ **Серкәң су күтәрмәү** — тәнкыйть-шелтәне яратмау, бик үпкәчел булу.— *Синең бер дә серкәң су күтәрми башлаган.* Т. Гыйззәт. *Ул, егетнең серкәсе су күтәрмәвен бик тиз абайлап алып, көлүеннән туктый.* Г. Минский.

СЕРКӘ II *и.* Бет, кандала кебек вак бөҗәкнең озынча күкәе. *Бер-берсенең чәч төпләреннән пычак очы белән серкә эзләүче карчыклар бу беткесез сагышны такылдык телләре белән туглыйлар.* К. Нәжми.

СЕРКӘ III *и.* Катык сыманрак әчкелтем, төссез сыекча (аш тәмләткеч дирбия); *русчасы:* уксус. *Серкә савыты.* □ *— Себер пилмәһенәрен ашаганың булса, әйтер идең ичмасам аш дип. Борычлап, серкә салып җибәрсәң, телеңне йотарсың.* Н. Дәүли.

СЕРКӘЛЕ I *с.* Серкәсе (I), серкәләре булган. *Арышның серкәле чоры.*

СЕРКӘЛЕ II *с.* Өстендә яки эчендә серкәләре (II) булган, серкәләгән (баш, чәч һ. б. турында).

СЕРКӘЛЕ III *с.* Серкә (III) салынган, катылган (аш турында). || Серкә салып куелган, эчендә серкә булган (шешә һ. б. ш. савыт турында).

СЕРКӘЛЕК *и. бот.* Серкәчнең өске, серкәле өлеше; *русчасы:* пыльник. *Серкәлектә бик вак бөртекчәләр — серкәләр була.* Ботаника.

СЕРКӘЛӘНДЕРҮ *ф.* Үсемлектә: серкәне (I) аналык органнарына күчерү. *Ясалма серкәләндерү.*

СЕРКӘЛӘНҮ *ф. бот.* Үсемлектә: җимешлеккә (аналык органына) серкә I күчү. *Ачык урынга утыртылган кыярларның җил яки бөҗәкләр ярдәмендә серкәләнүе.* □ *Алмагачларны сортлап утыртырга, үзара серкәләнергә тиешле сортларны — янәшә, үзара серкәләнмәскә тиешлеләрен бер-береннән ерак итеп урнаштырырга [кирәк].* И. Гази. *Тыныч кына яңгыр явар Арыш серкәләнгәндә.* Ә. Ерикәй.

СЕРКӘЛӘҮ *ф.* Үзендә вак бөҗәк серкәләре барлыкка килү (баш, чәч һ. б. турында).

СЕРКӘЧ *и. бот.* Чәчәктә: серкәлектән һәм анын җепсел сыман сабакчыгыннан гыйбарәт бер орган; *русчасы:* тычинка. *Чәчәкле үсемлекләрнең бер-береннән серкәчләреның саны һәм төзелеше буенча аерылуы.* □ *Кояш көннән-көн ныграк кыздыра. --- Агачларның коры ботакларына җан керде. Зирек агачында былтыр көздән әзер булып калган алкаларда тәңкәләр хәрәкәткә килде, тал мамыкларында алтын сыман серкәч күренде.* М. Максуд.

СЕРЛЕ *с.* 1. Үзлекләре әлегә ачылмаган, танып беленмәгән. *Табигатьнең серле күренешләре.* □ *Гыйшык аның өчен Бер тылсымлы, серле көч иде.* М. Җәлил. *[Халикъ] өстәлгә өсте ак җәймә белән ябылган ниндидер бер серле әйбер китереп куйды.* Г. Әпсәләмов.

2. Кешегә белдерергә ярамаган, яшерен. *Серле сөйләшүләр.* □ *Сафия аның [егетнең] хәрәкәте, сүзләреннән аның белән Лутов арасында ниндидер серле мөнәсәбәт барлыгын сизенеп, шуны белергә тели.* Г. Нигъмәти. || Шомлы, шикле. *Җир казучылар янында Галләм белән Архиповның сөйләшеп торулары аңа [Садыйкка] томанлы һәм йөрәк әрнеткеч серле булып күренә.* Ш. Камал. || Аңлавы-төшенүе кыен булган һәм сәер. *Серле елмаю. Серле кеше. Серле сорау.* □ *Җыелган җәмәгатьнең йөзенә серле аптырау чыкты.* Г. Ибраһимов. || Сәер һәм шигъриятле. *Тау буена бар син язның Серле, айлы кичендә.* Ф. Кәрим. *Зәңгәр күзләр елмаялар — Серле матурлык анда.* Ә. Ерикәй.

СЕРЛЕЛЕК *и.* Серле булу сыйфаты, хәле; серле нәрсәгә яки кешегә хас сыйфатлар. *Табигатьнең искиткеч серлелеге аңарда табигать көченә ихтирам уята, аны дулкынландыра, хәтта көнләштерә иде.* Г. Бәширов. *Яр буйларындагы агачлар суда баштүбән чагылган. Аларның чагылышы күлгә тирәнлек белән бергә серлелек өсти.* Г. Әпсәләмов.

СЕРЛЕЛӘНҮ *ф.* Серлегә әйләнү; аңлашылмас, сәер хәлгә килү. *Җәмил бергән төргәк сере әбәт вакытында тагын да серлеләнә төште.* Г. Гобәй. *Бер караганда ул элекке Галия, бер класста укып йөргән иптәш кыз булса, икенче күргәндә бөтенләй ят кешегә әйләнә, серлеләнә, ерагая.* Ф. Яруллин.

СЕРЛӘШҮ *ф.* Башкалардан яшереп, ишеттермичә, үзара гына сөйләшү. *Язны сөешү һәм серләшү вакыты диләр шагыйрьләр.* М. Җәлил. *Аның берәр якын дусты белән бик иркенләп, бик үз итеп сөйләшеп утырасы, серләшәсе килә башлады.* Г. Бәширов

СЕРПАНТИН *и.* Балда, зур кичәдә танцевать итүчеләр, маскарадта катнашучылар өстенә сибеп ташлый торган, төсле озын кәгазь тасма.

СЕРӘЮ *ф.* 1. Бераз вакытка катып калу (кеше, гәүдә турында).

2. *рәв. мәгъ. сөйл.* **серәеп.** Күңелсез тәэсир калдырыр дәрәҗәдә төз катып, сәер тураеп (утыру, тору, урнашу турында). *Серәеп утыру.* □ *Авылларның салам башлы өйләре арасыннан өскә чыгып, серәеп торган кое баганалары* [*күзгә бәрелде*]. М. Гафури.

СЕ'ССИЯ *и.* **1.** Төрле вәкиллекле органнарның, оешмаларның, коллегиаль учреждениеләрнең һ. б. ш. билгеле бер срок үткән саен яки зарур булган очракта чакырыла-ясала торган җыелыш-утырышы; шушы җыелыш дәвамындагы вакыт. *Шәһәр советы сессиясе. Судның күчмә сессиясе.* □ *— Нургали абый, фермаң турында доклад ясарга хәзерлән, якын көннәрдә авыл советы сессиясендә сине тыңларбыз.* Ә. Еники.

2. Югары һәм махсус урта уку йортларында: сынау бирү чоры һәм шул вакыт дәвамындагы сынаулар. *Җәйге сессиядә яңа лекцияләр тыңлау.* □ *Сания читтән торып техникумда укый, төннәр буе сессиягә хәзерләнә.* Соц. Тат.

СЕСТРА *и. махс.* Дәвалау йортларында: урта медицина хезмәткәре. *Госпитальдә сестра булып эшләү. Палата сестрасы. Өлкән сестра. Хирургия сестрасы.*

СЕСТРАЛЫК *и.* Сестра вазифалары һәм хезмәте. [*Фронтка җибәрегез дип үтенүче кыз:*] *Мин сестралыкка укып чыктым, мин пулеметтан ата беләм, бөтенесен беләм!* Г. Бәширов.

СЕ'ТКА *и. сөйл.* Азык-төлек һ. б. салып хуҗалык сумкасы урынына йөртә торган кечкенә җәтмә капчык. *Капрон сетка. Ефәк сетка. Базардан сетка белән яшелчә алып кайту.* □ *Әйберләр белән мәшәкатьләнеп йөрмәбез. Җиңелчә генә, кунакка барган шикелле генә: бер кулда сумка, икенчесендә сетка.* Г. Мөхәммәтшин.

СЕҢГЕРҮ *ф.* Эчкә алган һаваны кинәт чыгарып, борын эчен лайлалы сыекчадан чистарту. [*Шәмәк*] *бер бармагы белән танавын тотып сеңгерә.* К. Тинчурин. [*Мич белән моржаны тазартып чыккач*] *тануларыбызны сеңгерсәң, кызыл тузан белән көл катыш нәрсә чыга.* М. Гафури.

СЕҢДЕРҮ *ф.* **1.** Сыекча, газ кебек нәрсәне: сеңәрлек итеп әйбернең эченә кертү, үткәрү. *Багананың җиргә утыртасы башына дегет сеңдерү. Тукымага су үткәрми торган матдә сеңдерү. Киемгә нафталин исе сеңдерү. Буяр алдыннан тактага олиф сеңдерү. Мамыкка спирт сеңдерү.*

2. Сеңә торган нәрсәне үз эченә алу; шундый үзлеккә ия булу (төрле нәрсәләр турында). *Комның суны тиз сеңдерүе.* □ *Күп гасырлардан бирле әллә ни хәтле кан елгалары, хәсрәт яшьләре сеңдерә килгән җир йөзе саф су белән юынды.* Ш. Камал.

3. *күч.* Күңелдә-хәтердә нык калырлык итеп аңлату, өйрәтү (белемне һ. б.). *Без шул идея һәм карашларны массаның аңына сеңдерергә тиешбез.* М. Җәлил. *Озата килгән аталар һәм аналар үз балалары янында чөкердәштеләр; --- колакларына яхшы сүзләр сеңдереп җибәрергә тырыштылар.* Ә. Бикчәнтәева.

4. *күч.* Күңелгә-хәтергә нык алу. *Олылар сүзен күңелгә сеңдереп кую. Сәяхәттә күргәннәрне хәтергә сеңдерергә тырышу.* □ *Хәлим җиңү шатлыгын аңына сеңдереп, бөтен йөрәгеннән --- уйный иде.* Г. Гобәй.

5. *күч. гади с.* Сугып-кыйнап һ. б. ш. рәвештә тора-кузгала алмаслык итү, егу. *Алып Закир башта* [*карақларның*] *пычаклысын сугып сеңдерә һәм бәрәңге базына тибеп төшерә, аннары берәм-берәм тегеләрен дә.* Г. Гобәй.

СЕҢЕЛ, СЕҢЛЕ *и.* **1.** Үзеңнән кече кыз туган. *Сеңлесенә сүз әйтмәгез — апасына күз тия.* Г. Тукай. *Большевикларча сәлам, сеңлем.* М. Җәлил. *Аның янында кечкенә сеңлесе дә бар.* Һ. Такташ.

2. сеңлем. Үзеңнән яшь хатын-кызга мөрәҗәгать сүзе.— *Сез кем кызы буласыз, сеңлем?* Г. Ибраһимов.

СЕҢЕР *и.* Скелет мускулларын сөяккә тоташтыра торган, бик тыгыз һәм сыгылма җепселле тукыма; *русчасы:* сухожилие. *Тез асты сеңерләре.* □ *Карт сары сеңердән генә торган муенын Хәлимгә таба сузды.* И. Гази.— *Бай безне кыйнатты. Сеңердән үргән камчы белән башыма сугып, башымны ярдылар.* Ә. Айдар.

СЕҢЕРЛӘНҮ *ф.* Сеңер кебек сыгылмалы хәлгә килү.

СЕҢЕРЧӘ *и.* **1.** Нечкә, вак сеңер.

2. Яфракта һәм бөҗәк канатында: озынча буынтык сыман тамыр. *Яфрак сеңерчәләре.*

СЕҢЕШ *и.* Сеңү хәрәкәте, процессы һәм үзлеге. *Һәрбер азыкның химик составы һәм ул матдәләрнең сеңеше химик лабораторияләрдә сынаулар аркылы билгеле булган.* А. Расих.

СЕҢҮ *ф.* **1.** Берәр нәрсәнең эченә үтеп, аның күзәнәкләре, кисәкләре арасында таралу (сыеклык, ис һ. б. ш. турында). *Ява яңгыр, сеңә җиргә.* М. Гафури. *Дегет агачка нык сеңгән иде.* Г. Ибраһимов. *Шул килгән саен өйгә тәмәке сасысы сеңеп кала.* И. Гази.

2. Нык кереп урнашу (хәтергә, күңелгә). *Кайбер истәлекләрнең күңелгә сеңүе.* □ *Бергә әшләгән вакытта бу кеше турында хәтеренә сеңеп калган хәлләрне күңеленнән уздырды ул.* М. Зарипов. *Бик күпләргә кечкенәдән үк таныш булган һәм йөрәкләренә мәңге онытылмаслык булып сеңеп калган бу таныш көй --- тыңлаучыларның колакларын торгызды.* Г. Әпсәләмов.

3. *күч.* Нык иелеп, ятып һ. б. ш. рәвештә күренмәскә тырышып посу. [*Һава һөҗүме башлангач*], *ике куллап башымны учлаган килеш, җиргә тагы да ныграк сеңәргә тырышып йөзтүбән ятам.* Ә. Еники. *Бер почмакка сеңеп утырам да --- китап укыйм.* Ф. Хөсни.

СИ *и. махс.* **1.** Музыкаль авазлар системасындагы соңгы, җиденче тон.

2. Музыка әлифбасында: шушы тонны белдерә торган нота.

СИБЕЛМӘ *с.* Таркау, таралып яки чәчелеп ята (тора) торган. *Сибелмә саф.* □ *Кама буеның көнчыгыш районнарыннан берсендәге Полуденка елгасында геологлар сибелмә алтын ятмасы таптылар.* Соц. Тат.

СИБЕЛҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сибү (1—8 мәгъ.).

2. Тәртипсез таралып коелу, чәчелү. *Өстәл өстендә ачылган консервлар, хатын-кыз кулы тимәгән бер кофейник тора һәм кумач, колбаса кисәкләре белән аралашып алмалар, виноградлар сибелеп ята.* А. Шамов.

3. Чыгып таралу, бөркелү (нур, ис һ. б. ш.). *Очкын сибелү.* □ *Тирә-якка сары яктылык сибелде.* Г. Гобәй. *Агач ботаклары арасыннан бүлмәгә җәйге җылы кояш нурлары сибелә.* А. Шамов.

4. Таралышу, төрле якка китү. *Урам уртасында йокыга талган ап-ак каз көтүе куркынып як-якка сибелде.* Г. Бәширов. *Йортлар киң кырларга сибелеп утырганнар.* Г. Гали. *Чәчелгән, сибелгән татар, Яфраклар очкан сыман; Тараларга туган якларын Калдырган кошлар сыман.* Н. Арсланов.

СИБӘЛӘҮ *ф.* **1.** *Каб. дәр. к.* сибү (1—4 мәгъ.).

2. Җиңелчә генә яву. *Көзге вак яңгыр акрын, ләкин туктаусыз һаман сибәли иде.* Г. Ибраһимов. *Һава салкын, ләкин аз гына җылытkан. Кар сибәли.* Г. Әпсәләмов.

СИБҮ *ф.* **1.** Бөртекле яки вак кисәкле һ. б. ш. нәрсәләрне: чәчеп тарату. *Сукмакка ком сибү. Бозлавыкта урамга көл сибү.* □ *Самолет җиргә куктән*

Ашлама сибә. Ә. Юныс. *Бабаларыбыз ашлыкны тубалдан кул белән сибеп чәчкәннәр.* Каз. утл.

2. Бөртекле тәмләткечләрне: ашамлык өстенә бераз гына салу, аңа кушу. *Күкәйгә тоз сибеп ашау. Башакка он сибү. Ашка борыч сибү.* □ *Шат балаларның бәйрәмнәрдә, мәк сипкән ак булкалар күтәреп, бакча сукмакларында чабышып йөрүләренә сокланып караудан туймый идек.* Ә. Еники.

3. Бөртекле яки вак кисәкле азыкны кош-кортка: бирү, таратып салу. *Үрдәк-тавыкка бодай сибү.* □ *Тәрәзә ачып җимнәр сиптем, Ашагыз, кошкайларым.* Җыр. *Гата да чебешләрне Җамал әби төсле үк сөйде, - - - я су эчертте, я ярма сипте.* А. Алиш.

4. Сыеклыкларны: бөркү. *Гөлгә су сибү. Иске май сибү. Корткыч бөҗәкләргә агу сибү.* □ *Хатын-кызлар иртә таңнан килеп бу түтәлләргә су сипкән иделәр.* Ш. Камал.

5. Нурны, исне һ. б. ш. тарату, чыгару, бөркү. *Мәңге сипсен кояш җиргә нурын, Яшик җырлап тычыч хезмәт җырын!* Ә. Исхак. *Юкә агачлары тирәякка хуш ис сибәләр.* Д. Аппакова.

6. *күч. сөйл.* Яву (яңгыр, кар турында). *Кырпак сибеп үтү.* □ *Тышта шыбыр-шыбыр яңгыр ява; яңгыр сибә, яңгыр коела.* Ш. Маннур.

7. *күч.* Чамасыз күп сарыф итү, күпләп өләшү-тарату (акчаны, малны, бүләкне һ. б. ш.). *Төзелешләргә акчаны сибеп кенә тору.* □ [*Адвокат:*] *Вәли байның җәмәгать файдасына үз заманында эшләгәннәре — болар зур меценатның киң кул белән алтын, җәүһәр сибүе.* Г. Ибраһимов. *Колчак Уфада чагында подполковник Солодовников дәүләт алтынын уңга да, сулга да сибә.* Каз. утл.

8. Берьюлы күп коралдан яки өзлексез рәвештә ату. *Ут сибү.* □ [*Дошман*] *кинәт пулеметтан сибә башлый.* И. Гази.

9. *күч. сөйл.* Бик оста, җитез сөйләү, җырлау, бию, музыка уйнау һ. б. ш. *Ул мактау сүзләрен кызганмый сибә иде.* А. Шамов. *Казаннан килгән егет, Оекчабата киеп; Монда килеп, итек киеп Нишләп йөрисең биеп? Һайт! Сип!* М. Фәйзи.— *Ач тамак белән җырның рәте булмас, иң элек ашап алыйк әле,— диде ул. - - - Ашап туйгач, тагы Шәйдул тавышы яңгырады:— Менә хәзер сибәргә була!* К. Латыйпов.

СИГА'РА *и.* Кәгазьсез тарту өчен таякчык (карандаш) сыман итеп һәм тыгызлап махсус төргән тәмәке эфрагы.

СИГА'РАЧЫ *и.* **1.** Сигара эшләүче яки эшләп чыгартучы яисә шуның белән кәсеп-сәүдә итүче. *Сигарачы магнатлар.*

2. Сигара (күп) тартучы тәмәкече.

СИГАРЕТ *и.* Бик юка кәгазьгә төреп (эчендә папиростагы кебек бушлык калдырмыйча) эшләнгән тәмәке. *Фильтрлы сигарет. Сигарет фабрикасы. Импорт сигарет. Сигарет кабы.*

СИГАРЕТЛЫ *с.* **1.** Эчендә сигареты-сигаретлары булган, бушамаган (кап һ. б. ш. турында).

2. Янында, үзе белән сигареты булган (кеше турында). || Авызына сигарет капкан.

СИГАРЕТЛЫК *с.* Сигарет алырга дигән яки шуңа китәрлек (акча турында).

СИГЕЗ *сан.* **1.** Җидедән соң килеп, 8 санын, микъдарын һәм цифрын белдерә.

2. *гадәттә кыек форм., сөйл.* Сигез яшь. *Сигезе пулып кына килә торган кыз. Сигезгә яңа чыккан бала.* □ *Урак өстеннән бирле сигез белән бара инде улым.* Сөйләмнән.

3. сигезе. Сигезенче число; календарьның сигезенче көне. *Октябрь бәйрәменең икенче көне ноябрьның сигезенә туры килә.*

СИГЕЗАЯК *и. зоол.* Куәтле һәм зур-зур сигез капшавычлы ерткыч диңгез хайваны; спрут.

СИГЕЗЕНЧЕ *Тәрт. саны. к.* сигез (1 мәгъ.). *Семьядагы сигезенче бала. Сигезенче класс. Өйнең сигезенче каты. Журналның сигезенче номеры.*

СИГЕЗЛЕ *с.* **1.** Цифр турында: 8 санын белдерә торган. *Сигезле цифр.* || Әйбернең зурлыгы-размеры турында: шул үлчәмле. *Сигезле галош. Сигезле лампа. Сигезле ачкыч.*

2. *и. мәгъ.* 8 цифры. *Сигезлене матур итеп яза белмәүче. Гарәп һәм рим цифрлары системаларында сигезленең төрлечә күрсәтелүе.*

СИГЕЗЛЕК *и.* Сигез күзле уен картасы. *Буби сигезлеге. Уен сигезлеге. Сигезлектән йөрү.*

СИГЕЗЛӘП *Чама саны.* **1.** *к.* сигез (1 мәгъ.).

2. *рәв. мәгъ.* Чыбыркы ишү, үрү һ. б. ш. турында: сигез рәтле-катлы итеп. *Сигезләп ишкән каеш чыбыркы.*

СИГЕЗЬЕЛЛЫК *и.* **1.** Сигез еллык мәктәп; тулы булмаган урта мәктәпнең бер төре. *Сигезьеллыкны тәмамлап һөнәр мәктәбенә керүчеләр.*

2. Сигез еллык вакыт, срок. *Уткән сигезьеллык нәтиҗәләрен алдагы сигезьеллыкның төп саннары белән чагыштыру.* || Сигез еллык план. *Сигезьеллыкны уңышлы төгәллә.*

СИГЕЗӘР *Бүл. саны. к.* сигез (1 мәгъ.). *Сигезәр борчаклы кузак. Сигезәр кешеле сафлар. Сигезәр кешелек палаткалар. Бер атнага дип китеп, сигезәр көн йөреп кайту. Сигезәр катлы йортлар. Сигезәр потлы капчыкларны җиңел күтәрүче егет.*

СИГЕЗӘРЛӘП *рәв.* Аеру-бүлү, тезү, урнаштыру турында: сигезәр-сигезәр итеп. *Төркемнәргә сигезәрләп бүлү.* □ *Вожатый дружинадагы пионерларны сигезәрләп бүлде һәм һәр төркемгә аерым-аерым задание биреп чыкты.* Ялкын. || Тезелү, урнашу, бүленешү һ. б. ш. турында: сигезәр-сигезәр булып. *Сафка сигезәрләп басу.*

СИГЕЗӘҮ *Җыю саны. к.* сигез (1 мәгъ.).

СИГНАЛ *и.* **1.** Төрлечә хәбәр тапшыру-белдерү өчен кулланыла торган шартлы әлемтә чарасы. *Тавыш, яктылык сигналлары. Механик сигналлар. Автомобильнең сигнал уты. Тимер юлчыларның сигнал лампаларын болгавы.* || Шул чарадан файдаланып бирелә торган шартлы хәбәр. *Электрны сүндереп-кабызып бирелгән сигнал. Кисәтү сигналы. Ракеталар белән сигнал бирү. Диңгезчеләрнең флаг болгап сигнал бирүе. Машина сигналына сискәнеп китү.* □ *Елга үрендәге берничә кеше ашыгып кулларын күтәрәләр; бу — боз кузгалу турында сигнал. Ул арада булмый, якынрак торган кешеләр дә кулларын күтәреп болгый башлыйлар.* Ә. Еники. || Шартлы команда. *Паровозга кузгалырга сигнал булу. Һөҗүм сигналын көтү.* □ *Сигнал булды бергә җыйналырга: Сузып-сузып бырғы уйнады.* С. Урайский.

2. *күч.* Берәр җитешсезлек турындагы кисәтүле хәбәр. *Партоешмага кергән сигналларның дөреслеген тикшерү. Кино хезмәте җитешсезлекләрен күрсәткән сигналларның редакцияләргә еш килеп торуы.* □ *— Якуп, сезнең эшегездә ниндидер чатаклыклар бар икән бит. Шул турыда сигналлар да бар.* Р. Ишморат.

3. *махс.* Берәр нәрсәнең булуын-яшәвен, хәрәкәтен белдергән-күрсәткән билге; аның организмга яки аппаратка тәэсир итеп чагылышы. *Ерак йолдызлыклардан килгән сигналларны кабул итү.* □ *Нерв җепләренең очлары - - - бик кечкенә тышкы ярсыткычларның җылылык, электромагнит сигналларын, химик, механик сигналларны кабул итәләр һәм нерв системасына тапшыралар.* Азат хатын.

СИГНАЛИЗА'ТОР *и.* Сигнал бирү җайланмасы-аппараты; шуның сигнал тапшыра торган кисәге. *Автомат сигнализатор. Янгын сигнализаторы.*

СИГНАЛИЗА'ЦИЯ *и.* **1.** Сигнал (1 мәгъ.) тапшыру хезмәте, сигнал (яки сигналлар) ярдәмендә хәбәр бирү эше. *Сигнализация ике сәгатькә соңга кала.* А. Тимергалин.

2. *җый.* Сигналлар (1 мәгъ.), аларның системасы. *Диңгез сигнализациясен өйрәнү. Шоссе һәм тимер юл сигнализацияләре.*

3. *җый.* Сигнал җайланмалары-аппаратлары системасы. Сигнализация кору. *Кибет биналарындагы сигнализация.* □ *Анда Үзәк идарә пульты. --- Ишеге бикле аның. Көн саен пломба салып торалар. Сигнализацияне үзмичә кагылсаң, бөтен дөньясын кубарып кыңгырау шалтырый башлый.* А. Тимергалин.

СИГНАЛЧЫ *и.* Сигнал (1 мәгъ.) бирүче. [*Капитан*] *сигналчыга нидер әйтте. Сигналчы шунда ук безнең якка борылды, кулындагы кызыл флаглары белән берничә мәртәбә болгап алды.* С. Сабиров.

СИГӘК *с. гади с.* Йоклап ятканда астына сиюче яки сидеген тота алмаучы.— *Сигәк диләр бит аны, төннәрен урыны лычма була ди.* А. Гыйләҗев.

СИГӘКЛӘҮ *ф. гади с.* **1.** Сигәккә әйләнү (чирләү).

2. *күч.* Намуссыз ялагайлану, әләкләү, тиешсезгә зарланып елау һ. б. ш. *Сигәкләп йөрүче куштан.*

СИДЕК *и. физиол.* Организмда эшкәртелгән матдә калдыклары белән бергә бөердән бүленеп чыга торган сыекча; *русчасы:* моча. *Лабораториядә сидекнең составын тикшерү. Сидек юлы.*

СИЗГЕР *с.* Сизү тойгылары һәм хисе яхшы; тиз сизүчән. *Төрле искә сизгер булу.* □ — *Минем борын сизгер.* Н. Исәнбәт. *Тирә-якка бал исе сибелә, сизгер бал кортына гына түгел, бу ис безгә дә сизелә.* А. Алиш. *Сизгер ана кече улының чырае караңгы булуын шунда ук искәреп алды.* Г. Бәширов. *Уяу, сизгер булырга кирәк.* Ә. Еники. || Сизгерлекне белдерә, күрсәтә торган. *Сизгер адым.* □ *Алҗыган кешенең йокысы сизгер икән.* Каз. утл.

СИЗГЕРЛЕК *и.* Сизгер булу сыйфаты. *Табигать тарафыннан хатын-кызларга гына, анда да кайбер хатын-кызларга гына бирелә торган, кеше күңелендәге бик кечкенә үзгәрешләрңе дә тоя, күрә белү сизгерлеге Хәлимәдә артыгы белән бар иде.* Ш. Хөсәенов. *Ил чиген саклау эше кешенең сизгерлеген көчәйтә.* Г. Минский.

СИЗГЕРЛӘНҮ *ф.* Сизгергә әйләнү. *Күңел сизгерләнү.* □ *Ни өчендер сүзләргә бик сизгерләнделәр, серкәләре бер дә су күтәрми башлады егетләренең.* М. Шабаев. *Игеннәр арасыннан ара-тирә бытбылдыклар, тургайлар пырылдап очып чыгалар, болай да сизгерләнгән нервларны тынычсызлыйлар, сискәндереп җибәрәләр.* А. Шамов. || Сизгерлек күрсәтү. *Акыллыланган булып ахмаклыкта кала торган, сүзгә остарган булып, сизгерләнгән булып теге шомарган халык алдында көлкегә генә кала торган сала мужиклары* [*ашлык базарында күп очрый*]. Ф. Әмирхан.

СИЗДЕРМӘСТӘН *рәв.* **1.** Эш-хәрәкәт итү һ. б. ш. турында: сиздермичә, качып-яшереп кенә. *Сиздермәстән китеп баруыгыз бер дә килешмәде.* Ш. Камал. *Мәйсәрә,* [*кунакның*] *бушап калган чынаягын сиздермәстән генә алып, тагын да чәй ясады.* Г. Иделле.

2. Вакыт узу һ. б. ш. турында: сизелмичә һәм көтмәгәндә. *Яшь вакыт — чәчәк вакыт — сиздермәстән әнә шулай узар да китәр.* Г. Бәширов.

СИЗДЕРҮ *ф.* **1.** Сизәргә (2, 4 мәгъ.), белергә мөмкинлек бирү. *Шикне сиздермәү.* □ *Ничек тә булса серне сиздермәскә кирәк.* Г. Камал. *Бу авырлыкны мин кешегә сиздермичә күтәрергә тырыштым.* М. Әмир.

2. Сизелү, беленү (тышкы дөнья, төрле хәлләр һ. б. ш. турында). *Көн үткән саен, ялгызлык үзен ныграк сиздерә башлады.* Ә. Еники. *Аягым төзәлеп җиткән дип әйтерлек булса да, вакыт-вакыт авырткалап, үзен сиздерә иде әле.* Ә. Айдар. || Теләкне, ниятне, уйны һ. б. ш. читләтеп кенә аңлату, өлешчә генә белдерү. *Үпкәңне сиздереп хат язу.* □ — *Мин юкта, хатын, яучы-мазар килсә, мин кайткач җавап бирербез дисәң дә, ризалыгыбызны сиздереп куй!* М. Фәйзи. *Гаяз, җавап көткәнен сиздереп, бераз тукталып торды.* М. Әмир.

СИЗЕЛЕРЛЕК *с.* Игътибарны тартыр дәрәҗәдә; сизәрлек; шактый. *Егетләр сизелерлек тазара.* Ш. Усманов. *Һава сизелерлек салкынаеп китте.* Г. Әпсәләмов.

СИЗЕЛҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сизү.

2. Организмга тәэсир итү, беленү. *Арганлык сизелү. Авырту сизелү.* □ *Мылтык тавышы яңгырады. Ләкин пуля очкан тавыш сизелмәде. Һавага аткан тавыш булырга кирәк.* М. Гали. *Һавадан яз исе, кояш исе һәм сизелер-сизелмәс кенә булып бөре исе аңкый.* А. Шамов.

3. Төрле тышкы билгеләрдән беленү, күренү, аңлашылу. *Үзгәреш сизелү.* □ *Урта буйлы, таза гәүдәле, кызыл чырайлы бу картта көч, гайрәт барлыгы сизелеп тора.* Р. Ишморат. *Муллык сизелеп тора һәр җирдә.* Ә. Ерикәй. *Туташның үзенең дә сөйләшәсе килүе сизелә иде.* Г. Бәширов.

4. Беленү, ачылу, фаш булу (сер, хәйлә һ. б. ш. турында). [*Галләм:*] *Кайда соң бу Зөләйха ханым, күренми, сизелгәнче тизрәк сызасы иде бит.* М. Фәйзи. *Әмиржәннарның планнары шәһәрдә сизелде микәнни соң?* Ш. Камал. *Либреттоны тыңлаган вакытта берничә җитди кимчелеге сизелде.* М. Җәлил.

СИЗЕМ *и.* Сизү тойгысы һәм хисе. *Хайваннарның сиземе көчле булу.* □ *Мәдинә искиткеч музыкаль иде. Ул үзенең интуитив сиземе белән әледән-әле Хәбиргә ярдәмгә килде, үзенең музыканы сизә һәм тоя белүе --- белән әледән-әле Хәбирне таңга калдырды.* Ш. Хөсәенов. *Кайчагында ул, сүзне ишетүдән бигрәк, аны сизем белән аңлады.* М. Максуд.

СИЗЕМЛЕ *с.* **1.** Яхшы тоючан һәм сизүчән; сизгер. *Бармаклар сиземле булу.* □ *Кысыла һаман, ул* [*күңел*] *нечкәрә: Нечкә кыллар үтә сиземле.* С. Сөләймановa.

2. Бик йомшак селкенү-калтырауны, кечкенә тирбәнешне, үтә әкрен хәрәкәтләрне дә сизә, терки торган (аппаратлар турында). *Аеруча сиземле сейсмик аппаратлар.*

СИЗЕМЛЕЛЕК *и.* Сиземле булу үзлеге. *Бармакның сиземлелеге кимү. Тәннең сиземлелеге арту. Аппаратның сиземлелек дәрәҗәсен билгеләү.*

СИЗЕМЛӘҮ *ф.* Сизем ярдәмендә белү, аңлау; якынча гына сизү, чамалау; сизә-сизенә башлау. *Матурлыкны сиземли белү. Яңалыкны тиз сиземи алу.* □ *Лаборатория хезмәткәрләренең Карамалыга борчу алып киләселәрен баштан ук дөрес сиземләгән икән ул.* Каз. утл. *Яңа туган балага дөнья әкренләп ачыла. Яктыдан караңгыны яхшы гына аера алса да, ул әле аның ни икәнлеген аңламый. Ата-анадан күчкән сиземләү һәм аңлау сәләте аңарда бик тиз үсә, бик тиз ныгый бара.* Ә. Касыймов.

СИЗЕМЧӘН *с. сир.* Тою үзлеге көчле булган. *Организмның бик сиземчән булуы.*

СИЗЕҢҮ *ф.* Ниятне, серне һ. б. ш. белеп, аңлап алу; чамалау; өлешчә сизү. *Ул сүзнең нәрсә турында баруын бик тиз төшенеп, боларның да кем булуларын сизенә башлады.* Г. Минский. *Еш-еш пошкыруыннан, башын чайкап баруыннан ук сизенәм, үткен хайван булса кирәк.* Ф. Хөсни. *Эшнең ни белән бетәчәген*

сизенгән Акбуз бераз артка чигенде. Г. Гобәй. || Абайлап алу. *Ул үзенең төзәтеп булмастай зур ялгышлык эшләвен сизенеп, каушап китте.* Г. Бәширов.

СИЗЕРӘҮ *ф.* Кыршылып-юкарып, сирәкләнеп, туза төшү (тукыма һ. б. ш. турында). *Җиң очлары, тирсәк турылары сизерәү. Итәк очлары сизери башлау.* □ *Аның башында уңып, ямьшәеп беткән кубанка, өстендә сизерәп калган шинель иде.* Ш. Маннур. *Утыргычның кара күне сизерәп, сиртмәләре төртеп чыккан.* Каз. утл.

СИЗМӘСТӘН *рәв.* Үзең абайламаган, сизмәгән хәлдә; кинәт, көтмәгәндә. *Сәмигулла абзый ашыгып сикереп торуга, үзенең буй чамасын да онытып, сизмәстән башын түшәмгә бәрде.* М. Шәрифуллин.

СИЗҮ *ф.* **1.** Тою. *Ис сизү. Авырту сизү. Салкынны сизмәү.* □ *— Сизә шул салманың тәмен егет.* М. Фәйзи. [*Авыруның*] *инде кул һәм аяклары сизми, кузгалмый.* Ш. Камал. *Ул корык очындагы арканны бер айгырның муенына салды. Ләкин эләккән мал, --- белепме яки үзлегеннәнме, арканны сизүгә кире чигенде дә котылып китте.* Г. Ибраһимов.

2. Хис итү. *Үзеңне ялгыз итеп сизү үтерә бит ул!* И. Гази. *Сабый чакларындагы шикелле үк дуслык сизде ул үзендә Гөлгенәгә.* Г. Гобәй.

3. Хайваннарда: тою органнары ярдәмендә, гадәттә истән белү, табу. *Балыкларның җим исен сизеп җыелуы. Мәченең итне сизүе.* □ *Иснәнеп эт читтән чаба, Киекне сизә, тынмый.* М. Максуд.

4. Белеп-аңлап алу (серне, ниятне һ. б. ш.). *Хәйләне сизү.* □ *Сизде эшне Шүрәле дә, кычкыра да бакыра.* Г. Тукай. *Бара торгач, Песинең бу хыянәтен Хуҗа сизде.* М. Гафури. || Абайлау, белү (хәлне һ. б. ш.). *Сүзгә мавыгып, вакыт үткәнен сизмәү.* □ [*Мәче*] *күгәрченнәргә таба елыша. Күгәрченнәр, бичаралар, бер нәрсә сизмичә тыныч кына гөрлиләр.* И. Гази. *Малайлар да елмая һәм... мин дә елмаеп утыруымны сиздем.* Р. Төхфәтуллин. || Якынча, чамалап белү; сизенү. [*Уйнаучының*] *көе нәкъ татардагыча. Уйнавы да бик шәп, бик оста күренә. Шулай да нәрсәседер җитми. --- Зыя моны сизә, ләкин сәбәп вә хикмәтен бер төрле дә белә алмый.* Г. Ибраһимов. *Читен дә соң артык һич бер вакыт Күрешмәсне сизеп аерылу.* М. Җәлил.

СИЗҮЧӘНЛЕК *и.* Сизү үзлеге, тойгысы. *Спиртлы эчемлекләр тиренең сизүчәнлеген бик нык киметәләр.* Соц. Тат.

СИКЕЛТӘ *и. к.* сикәлтә. *Ул, кузладан сикереп төшеп, сикелтәләрдә чананы терәп барды.* Ә. Еники. *Карамый ул* [*атны кызганмый куучы малай*] *атның йөзе барга, Сикелтәгә, тауга, тирән карга.* Ә. Юныс. *— Илле сигез еллык тормыш юлымда мин әллә ни кадәр сикелтәләр, кискен борылышлар үттем.* Сов. әд.

СИКЕЛТӘЛЕ *с. к.* сикәлтәле. *Сүз остасы түгел иде* [*чыгыш ясаучы*], *сөйләве сикелтәле юлдан барган ватык арбаны хәтерләтә иде.* И. Рәмиев. *Сикелтәле күпердән әллә ничә арба берьюлы узган сыман гөрелдәп, күк күкрәде.* К. Нәҗми.

СИКЕРГЕЧ *и.* Ике очын ике кулга тотып, баш өстеннән һәм аяк астыннан үткәреп, гәүдә тирәли әйләндерә торган, очларына сап куелган киндерә сыман уенчык (астан үткәндә сикереп уздыралар); *русчасы:* скакалка.

СИКЕРЕШ *и.* **1.** Сикерү (1, 3, 5, 6 мәгъ.) хәрәкәте. *Сикергеч белән уйнаучы кызларның сикерешләрен карап тору. Йөрәк сикереше.* □ *Поши, ягез, инде сез мине тотыгыз, дигән сыман шаян гына сикереш ясап, кире борылды һәм урман куелыгы эчендә юк булды.* Ә. Фәйзи. || Сикерү (7 мәгъ.) процессы һәм нәтиҗәсе. *Сабакның буынга сикереше.*

2. Сикерү (1 мәгъ.) ярышы. *Сикереш китә — кем ераграк сикерә? --- Аунап-тәгәрәп, мәтәлчек атып уйныйбыз, баш аркылы сикереш башлана. Олы малайлар тагын хәрәмләшә.* Ш. Маннур. *Шатлыклары эчләренә сыймагач, ыргылып китеп, тупыл ботакларына барып куналар, сикерештән уйныйлар* [*чыпчыклар*]. Ш. Камал.

3. Сикерү (4 мәгъ.) фигыленнән ясалган исем. Сөйләгәндә яки уйлаганда бер фикердән, темадан икенчесенә кискен күчеш. *Уйларының сикерешенә юнәлеш бирү.*

4. *кит.* Сыйфат үзгәреше: иске сыйфаттан, хәлдән яңага кискен күчеш; кискен алга китеш. *Телдән иҗат итүдән язып иҗат итүгә күчкәч, иҗат процессында сыйфат сикереше ясала.* Х. Госман. *Дәгәр бөз халыкны дин сөреме нн әм им-томчылар тозагыннан тәмам азат итүгә ирешсәк, --- бик күп чирләрне бетерү юлында да алга таба зур сикереш ясар идек.* Г. Әпсәләмов.

СИКЕРЕШЛЕ *с. кит.* Иҗтимагый үсеш турында: сикерешләр (4 мәгъ.) аркылы үтә торган. *Сикерешле үсеш.* □ *Техниканың моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәдә үсеше аерым капиталистик илләргә тиз, сикерешләр белән башка империалистик илләрне узып китәргә мөмкинлек ача. --- Моннан бер төркем илләрнең тиз, сикерешле рәвештә үсүе, икенчеләренең үсеше тоткарлануы килеп чыга.* Политэкономия.

СИКЕРТКӘ *и. сөйл. к.* чикерткә.— *Игендәге сикерткәдәй сикермә.* Г. Тукай.

СИКЕРТМӘ *и. к.* сикәлтә (1 мәгъ.). *Сикертмәгә төшү.* □ *Бер генә урында да сикертмә юк.* Ф. Сәйфи-Казанлы. || Таудан чаңгы, чана шуганда сикертә торган калкучык. *Чаңгы белән сикертмәне егылмыйча үтү.*

СИКЕРТМӘЛЕ I *с. к.* сикәлтәле (1 мәгъ.). *Сикертмәле юл.* || Чаңгы, чана белән шуып төшкәндә сикертә торган, сикертмәсе булган (тау, калкулык турында). *Сикертмәле таудан чаңгы шуабыз.* Р. Батуллин.

СИКЕРТМӘЛЕ II *с. к.* сиртмәле. *Соң, юл бит ул. Нигә җырламаска, Синең моңың ерак таралгач, Шыгырдагач хәтта, көйгә килеп, Сикертмәле чыбык тарантас!* Ш. Мөдәррис. [*Машинаның*] *кабина эче җылы, --- алда да, янда да тәрәзәләр, урының сикертмәле күн кәнәфи күк.* Ш. Рәкыйпов.

СИКЕРТМӘЛӘҮ *ф.* Сикертмәлегә (I) әйләнү, сикертмәләр ясалып бозылу (юл, аяк асты турында). *Кышкы юлның тиз сикертмәләнүе.*

СИКЕРТҮ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* сикерү (1, 2 мәгъ.).

2. Җиңелчә генә югарыга ыргытып, чөеп алу (кулдагы нәрсәне). *Ул елмаеп, курчакны кочагына алып утырып тирбәтә башлый, сикертә, эндәшә, көлдергән, шаярган була.* М. Җәлил. [*Бәрәңгенең*] *буы бөркелеп тора; бармакларыңны пешерә-пешерә, учыңда сикертә-сикертә аласың.* Г. Бәширов.

3. Бәреп, кагып югарыга очырту, күтәртү. *Кыз балаларның туп сикертеп уйнавы. Дулкыннарның көймәне сикертүе.* □ *Зур-зур дулкыннар безнең пароходчыкны сикертә --- башлады.* Ф. Әмирхан.

4. Гәүдәнең берәр өлешен кискен хәрәкәтләндереп, күтәреп кую. *Каш сикерту.* □ *Шәрифҗан, иңбашын сикертеп, төшеп бара торган шинелен төзәтте.* И. Гази. *Мескен арык вә кечкенә ат, сыртына чыбыркы төшкән саен арт санын азрак сикертә вә ике якка чайкап ала да, йөрешен бер дә арттыра алмый иде.* Ш. Камал.

5. Нык селкетеп-калтыратып борчу (дыңгырдык юл яки шуннан бара торган транспорт турында). *Сикертә торган юл.* □ *Машина юлда шул кадәр сикерткән, әбине бер алга, бер артка чөеп йөрткән.* Г. Бәширов. || *з-сыз.* Дыңгырдык юлның яки транспортның нык

селкетеп-калтыратып борчуы турында. *Ул атны өермә урынына куалый башлый... Тарантасны сикертә, әле уңга, әле сулга бәрә.* М. Хәсәнов.

6. Чаптыру (атны һ. б.). *Бу сүзсезлек Госманга ошамый, ул атын сикертеп алгарак китә.* Ф. Хөсни. *[Бай] юлга чыкса, моны [ярлыны] узып китә, Юлның бер ягыннан сикертеп.* М. Гафури.

7. Сөйләгән, укыган, уйлаган вакытта: берәр темага, сүзгә, фикергә һ. б. ш. кагылмыйча, аларны калдырып узу. *Сикертеп уку. Сикертеп сөйләү.* □ *Бу хәлне [борчылуны] басар өчен, Шакир, ашыгып-ашыгып, үзенең хатирәләрен сикертеп алга күчерде.* Ф. Әмирхан.

8. *күч.* Бик нык җәфалау.— *Әле аның сикерәсе көннәре алда. Аны судта тагы да яхшырак сикертерләр әле.* Г. Камал. *[Патша армиясенә] баргач, сикертә башласалар, патша кызына түгел, үзеңнең Гайнижамалыңа да күз кыса алмассың.* М. Гали. *Балаларың күп булса, сикертәләр алар: бер минут тынгы бирмиләр.* Сөйләмнән.

СИКЕРҮ *ф.* **1.** Көч белән этенеп һәм аякларны баскан җирдән аерып, алга яки югарыга таба кискен ташлану, ыргылу. *Балаларның сикереп уйнавы. Мәченең мич башына сикерүе. Тиеннең ботактан ботакка сикерүе. Арбага сикереп менү. Озынлыкка сикерү.* □ *Сикереп карыйбыз — ботакларга буй җитми.* Ш. Маннур. *Эт аңа бер тын йөгерергә ирек бирде. Аннан тагын шаян һаулап тычкан өстенә сикерде.* Г. Гобәй. || Берәр нәрсәне, урынны аркылы сикереп узу. *Киртә сикерү. Чокырны сикереп чыгу.* || Югарыдан ташлану; сикереп төшү. *Түбәдән җиргә сикерү. Тәрәзәдән ишек алдына сикерү. Парашют белән сикерү.* □ *Мин атымның куе ялына Тотындым да җиргә сикердем.* Ф. Кәрим.

2. *күч.* Артыгын кылану, узыну. *[Гәрәй — үзенә каршы булган Мәхмүт турында:] Ярар. Карарбыз, күпме генә сикерерсең икән.* Ш. Камал. *[Бәдри — үзләреннән киткән асрау турында:] Сүз әйтмәгәнгә сикереп китте. Шушында ук тагын кире кайтып керер әле.* К. Әмири.

3. Җиргә, идәнгә бәрелеп, югарыга күтәрелү (туп һ. б. нәрсә турында). *Аның тубы бик матур иде. Кем белә, бәлки бөтен Казанда да әле андый матур туп булмагандыр. Аннары, ул бик яхшы сикерә дә иде.* А. Шамов. *Тәгәрмәчләр чокырга туры килде ахрысы, машина бик яман сикереп куйды.* Г. Әпсәләмов.

4. Сөйләгәндә, уйлаганда: кискен күчү (бер фикердән икенчесенә). *Карт белән бергә аның ике кызы башта --- бер әйбердән икенчегә сикереп, күп нәрсә өстеннән үтеп сөйләштеләр.* Г. Ибраһимов. *[Әхмәди] уйга батты. Әкрен генә җыелышка күчте. Аннан иртә беләнге вакыйгага сикерде, аннан тагы да артка-рак, үткән көннәргә --- сәяхәт итте.* Г. Иделле.

5. Берәр җирдән икенче җиргә ыргылып күчү (ут, ялкын һ. б. ш. турында). *Саламны тиз арада көчле ялкын камап алды. Ялкын ярсый-ярсый кыекка сикерде. Кыекка да ут кабынды.* Ф. Кәрим. *Күпер турысына җитәрәк, алдагы танкның өстенә ялкын сикерә.* И. Гази.

6. Нык калтырау-дерелдәү (йөрәк һ. б. ш. турында). *Менә йөрәгем дә сикерә башлады инде.* Г. Коләхметов. *Борын кимерчәкләрем сикерәләр; сизенәм — яхшыга түгел.* Ф. Хөсни.

7. Кискен үсеп китү (үсемлек турында). *Арышның сабакка сикерүе.*

8. *күч.* Бик авыр хәлдә калып нишләргә белми җәфалану, газапка дучар булу, газап-җәза тату. *Вакытында тырышмасаң, эшеңне тапшырганда сикерерсең: сыйфатсыз хезмәтең үтмәячәк.* Сөйләмнән.

СИКЕРҮЛЕ *с.* Сикереп уйный торган (хәрәкәтле уеннар турында). *Хәзер шәһәрдән әллә ниткән сикерүле бию өйрәнеп кайталар. Я ул бию түгел, я йөгерү түгел... Аулак өйдәге уеннар начар идемени?..* М. Мәһдиев. || Сикерү хәрәкәте-номеры да булган (спорт программасы, ярышы һ. б. ш. турында).

СИККАТИВ *и. махс.* Майларны тиз киптерә торган матдә (техник буяуларга кушу өчен кулланыла).

СИКСӘН *сан.* **1.** Сигез дистәне эченә алып, 80 санын һәм микъдарын белдерә.

2. *гадәттә кыек форм., сөйл.* Киксән яшь. *Сиксәнгә кадәр яшәү. Сиксәннең өске ягына чыккан картлар.*

СИКСӘНЕНЧЕ *Тәрт. саны. к.* киксән (1 мәгъ.).

СИКСӘНЛӘП *Чама саны. к.* киксән (1 мәгъ.). *Җыелышта киксәнләп кеше катнашты.*

СИКСӘНШӘР *Бүл. саны. к.* киксән (1 мәгъ.). *Киксәншәр сум акча алу.*

СИКӘЛТӘ *и.* **1.** Транспортның тигез йөрешенә комачаулый торган чокыр-чакыр, юлдагы казылма яки калкучык; сикертмә. *Юл сикәлтәсе.*

2. *күч.* Эштәге-тормыштагы каршылык-кыенлык, вакытлы уңышсызлык.

СИКӘЛТӘЛЕ *с.* **1.** Транспорт юлы турында: сикәлтәсе-сикәлтәләре булган, тигезсез.

2. *күч.* Тормыш юлы һ. б. ш. турында: көйле-шома гына түгел, кыенлык-каршылыклар аша да үтә торган.

СИЛ *и.* Таулы җирдә көчле яңгыр яки кар әрү сәбәпле барлыкка килә торган хәтәр ташкын. *Сил төшү. Силнең көтүләрне, тирмәләрне агызып алып китүе. Яңгыр силе. Кар силе.*

СИЛИКАТ *и.* **1.** Составында кремнезём булган минералларның гомуми исеме.

2. Силикаттан (1 мәгъ.) эшләгән-ясаган нәрсәләрнең гомуми исеме. *Силикат эшләп чыгаручы завод. Силикат цехы.*

3. *с. мәгъ.* Силикаттан (1 мәгъ.) эшләгән-ясаган. *Силикат продукция. Силикат кирпеч. Силикат эшләнмә.* || Силикаттан (2 мәгъ.), силикат эшләнмәләрдән төзелгән-корылган. *Силикат стена.*

СИЛИКАТЛАУ *ф.* Силикат (1 мәгъ.) катнаштыру.

СИЛИКАТЧЫ *и.* Силикат (2 мәгъ.) җитештерүдә эшләүче. *Силикат заводына тагын да күтәренкерәк план бирелде. Силикатчыларның ярдәм итәчәгенә ышанып, Татарстандагы төзелеш оешмалары да быел күтәренке программа билгеләделәр.* Соц. Тат.

СИЛЛА'БИК *с. әд.* Сүзләрнең басымын исәпкә алмыйча, юлларындагы иҗекләр санының тигез булуына гына нигезләнгән ритмлы (шигырь турында), шундый төзелешле (шигырь системасы турында).

СИЛЛОГИЗМ *и. лог.* Фикерләү ысулы: ике хөкемгә таянып өченчесен (нәтиҗәне) чыгару.

СИ'ЛОС *и.* Үсемлек массасын яшел килеш турап (вак булса — шул килеш), чокырда һ. б. ш. җирдә махсус ачыту юлы белән әзерләнә торган сусыл мал азыгы. *Көнбагышны силоска турату. Кукурузны силоска салып бетерү. Силосны вакытында салу. Силос базы.* □ *Кукуруз иң югары сыйфатлы силос бирә.* А. Расих.

СИЛОСЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* силослау. *Күпме үлән силосланганлыгын исәпкә алып бару.* || Үсемлек турында: силоска яраклы булу.

2. Силоска әйләнү. *Тиз силослана торган үсемлек.*

СИЛОСЛАУ *ф.* Силос итү, шул рәвешле хәзерләп кую. *Кукуруз силослау. Яшел борчакны силослау.* || Силос итеп турау, силоска эшкәртү (машина турында).

СИЛОСЛЫ *с.* **1.** Силосы булган, силос салынган-төялгән. *Силослы чокыр. Силослы чана.*

2. Силос кушкан-өстәгән (азык, рацион турында).

СИЛОСЛЫК *с.* Силоска дигән яки шуңа ярарлык (үсемлек турында). *Соң чәчелде бит: өлгерсә дә, силослык кына була бу көнбагыш.* Сөйләмнән.

СИЛУЭТ *и.* 1. Бер төс өстенә икенче төс белән төшергән яки уеп-кисеп ясаган сурәт. *Стенага силуэт элеп кую. Кош силуэты.*

2. *кит.* Әйбернең-объектның бик ерактан караганда яки караңгыда әз-мәз генә шәйләнә торган күренеше, рәвеше, сызымтасы. *Томандагы пароход силуэты. Шәһәр силуэты. Манара силуэты.* □ *Айлы төн булса, Волгадан пароходлар үткәне күренер иде. Дөм караңгыда Свияжск күперенең силуэты да күренми.* М. Максуд.

3. Архитектура-скульптура сәнгатендә: бинаның, әйбернең контуры, тышкы күренеше, тышкы сызыклардан гыйбарәт рәвеше. || Гомумән сынлы сәнгатьтә: әйбернең тышкы рәвеше, чикләре-читләре формасы. *Мода журналында бирелгән күлмәк, пальто силуэтлары. Плащның силуэтын яратмау.*

СИЛӘ *и. к.* сиртмә (2, 3 мәгъ.). *Әни мине каен силә асып Тирбәткән.* Ш. Маннур.— *Арт яктан тарантас силәсенә кыстырылган чалгы* [*күренеп тора иде*]. С. Рафиков.

СИМБИОЗ *и. биол.* Үзгә төр ике организмның бергә органик кушылып үсү-яшәү күренеше. *Ике үсемлек симбиозы. Ике хайван симбиозы. Хайван белән үсемлек симбиозы.*

СИ'МВОЛ *и.* Берәр абстракт төшенчәне яки идеяне белдергән шартлы билге. *Хезмәт символы. Җиңү символы.* □ *Күгәрчен — тынычлык символы ул.* Н. Исәнбәт. *Әкиятләрдә, бигрәк тә халык җырларында сандугач гел уңай образ итеп, үзенә бер саф лык һәм мәхәббәт символы итеп алына.* Р. Төхфәтуллин. *Бүләкнең әһәмияте аның ниндидер „байлык“ булуында түгел, бәлки якынлык һәм туганлык символы булуында.* М. Максуд. *Кызыл флаг — Совет власте символы.* Соц. Тат.

СИМВОЛИЗМ *и.* Империализм чорының (XIX йөз ахыры һәм XX йөз башлары) буржуаз әдәбиятында һәм сәнгатендә: чиктән тыш индивидуализм һәм динчелек белән сугарылган антиреалистик юнәлеш. *Символизм, декадентлык үтәдән-үтә эгоистик индивидуализм, дини мистика белән сугарылган. Символизмның, декадентлыкның максаты җәмгыятьнең котылгысыз социалистик революциягә алып бара торган үсешен туктатырга маташудан, көчләр арасына таркаулык кертергә омтылудан тора.* Х. Госман.

СИМВО'ЛИК *с.* Символ булып тора торган, шуның функциясен үти торган. *Символик билге. Символик рәсем. Символик сыннар. Символик хәрәкәт.* || Символ белән белдерелгән, сәнгатьчә шартлы. *„Хат ташучы“ поэмасы Мәскәүгә дан җырлый торган символик мәгънәле юллар белән тәмамлана.* М. Максуд.

СИМВО'ЛИКА *и.* 1. Берәр нәрсәнең символик мәгънәсе. *Чәчәкләр символикасын өйрәнү. Саннар символикасы.*

2. *җый.* Символлар, аларның җыелмасы. *Пионер символикасы.*

СИМВОЛИСТ *и.* Символизм тарафдары. *Әдәбияттагы һәм сынлы сәнгатьтәге символистлар.*

СИМВОЛИ'СТИК *с.* Символизмга мөнәсәбәтле. *Кабарынкы сүзләрдән генә торган бу символистик парчаларны (соңгы икесен) элеккерәк бер җыентыгымда хәтта бастырып та чыгардым кебек. Ләкин соңыннан аларны бер җыентыгыма да кертмәдем.* Ф. Хөсни.

СИМВОЛЛАШТЫРУ *ф.* Символга әйләндерү; символлар белән сурәтләү. [*Спектакльдә сукыр кеше булып уйнаучы артист*], *егылып китмәс өчен, сак кына атлый. Болай капшана-капшана юл эзләү аның тормыш юлын эзләвен символлаштыра.* Соц. Тат. *Әсәрдәге сурәтләр — символик сурәтләр. Алар нинди дә булса абстракт идеяләрне символлаштыралар.* Г. Нигъмәти.

СИМЕЗ *с.* 1. Бик майлы (ит турында). *Күп һәм симез ит белән озак кайнаган бу шулпа бик көчле, бик тәмле, бик туклыклы иде.* Г. Ибраһимов.

2. Тәнендә май күп булган.— *Бозауны карадым, бик көр, симез, таза бозау.* Т. Гыйззәт. *Су буеннан алпан-тилпән килеп симез үрдәкләр менәләр.* А. Әхмәт.

СИМЕЗЛЕК *и.* 1. Симез булу сыйфаты һәм дәрәҗәсе (ит, тән һәм хайван турында). *Гыймран агай бер кулы белән тананың мөгезеннән кысып тотып, икенче кулы белән --- җилен тирәләрен капшап карады: симезлеген тикшерде.* Г. Ахунов.

2. Симез булу хәле (кеше турында). [*Байбичә*] *симезлеге аркасында кешечә йөрүен онытkан.* М. Җәлил.

СИМЕРТҮ *ф.* Махсус ашатып симез итү (сугымлыкны). *Каз симертү.* □ *Кукуруз — мал симертү өчен бик әйбәт азык.* А. Расих.[*Мостафин*] *дуңгыз алып симертергә куйды.* Ә. Еники.

СИМЕРҮ *ф.* Симез (2 мәгъ.) хәлгә килү. *Бер елны шулай, көз көне мал-туар симергәч, Шәйхелислам абзый үгез сатарга җыенган.* Г. Галиев.

СИММЕ'ТРИК *с. к.* симметрияле. *Чәчәкләрне симметрик тәртип белән утырту.*

СИММЕ'ТРИЯ *и.* Берәр нәрсәнең өлешләре, кисәкләре урталыкка-үзәккә карата тигез ераклыкта тору хәле, күренеше; бер бөтенне тәшкил итә торган нәрсәләрнең урнашу тәртибендәге пропорциональ тигезлек. *Геометрик фигуралар симметриясе. Йөз симметриясе.* □ *Әгәр берәү матурлыкны кешенең авыз, борын, каш симметриясеннән генә эзләсә һәм әгъзалар гармониясен матурлыкның идеалы итеп таныса, безнең Катя аңа ошамас иде.* И. Гази.

СИММЕ'ТРИЯЛЕ *с.* Симметриягә нигезләнгән төзелешле, формалы. *Чәчәкнең симметрияле төзелеше. Йортның нигезен симметрияле итеп салу.* □ *Әйтерсең лә шагыйрь бер селтәнүдә күпмедер чәчәк ыргытkан да, ул чәчәкләр нәкъ тиешле җиренә, симметрияле булып сибелгәннәр, һәм матур бер букет барлыкка килгән.* М. Максуд.

СИМПО'ЗИУМ *и.* Берәр махсус (гадәттә фәнни) тема, мәсьәләгә багышлап үткәрелә торган киңәшмә. *Халыкара симпозиум. Физиклар симпозиумы.*

СИМПТОМ *и. кит.* Чирнең, кичерешнең һ. б. ш. тышкы, күзәтеп була торган билгесе. *Ул әтисенең сәер тоелган сүзләрен, баш әйләндергеч хәрәкәтләрен акылдан шашу симптомнары итеп аңлады, һәм яшь врачның керфекләре кайнар күз яше белән чыланды.* Г. Кутуй. || Гомумән, берәр хәл яки күренешнең беленә башлаган тышкы билгесе. *Экономик кризис симптомнары.*

СИМУЛЯНТ *и.* Авыру, сәләтсез һ. б. ш. булып кыланучы. *Никодимовны симулянтка санап яттылар бит. Ә аңарда чынлап та бизгәк.* К. Нәҗми.

СИМУЛЯНТЛАНУ *ф.* 1. Симулянтлык итү яки эшләү. *Симулянтланып йөрү.*

2. Симулянтка әйләнү.

СИМУЛЯНТЛЫК *и.* Симулянтка хас сыйфатлар; чирле, сәләтсез һ. б. ш. булып кылану күренеше. *Бик озак баш ваткаННан соң берәү: — Симулянтлык — менә сәбәп нәрсәдә! — дип куйды.* Чаян.

СИМУЛЯ'ЦИЯ *и. кит.* Симулянтлану күренеше; симулянтлык. *Симуляция ясау.* □ [*Врач — егеткә:*] *Симуляция белән йөрисең.* Ш. Маннур.

СИМФО'НИК *с. муз.* Кыллы, тынлы һәм чирттереп яки бәреп уйнала торган уен кораллары белән башкару өчен булган яки шул кораллар белән башкарылган. *Симфоник музыка. Симфоник поэма. Симфоник оркестр. Симфоник концерт.*

СИМФО'НИЯ *и.* Оркестр өчен язылган зур күләмле музыка әсәре. *Бу хезмәтләр татар совет музыкасының үсешендә аерым хәлиткеч роль уйнадылар һәм бүген операсы, симфонияләре булган музыкабызның үсү тарихында үтелергә тиеш булган һәм үтелгән дәвер булып торалар.* М. Җәлил.

СИН *а. 2-зат. бәрл.* **1.** Берәр кешегә турыдан-туры мөрәҗәгать иткәндә кулланыла. [*Шагыйрь — сабыйга:*] *Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын.* Г. Тукай.

2. Билгесез ияле яки гомумиләштерелгән мәгънәле җөмләләрдә: гомумән, кешене белдерә. *Безнең илдә юк оятлы һәм кадерсез һичбер эш. Һәрбер эштә син алдын һәм Данлы булырга тиеш.* М. Җәлил.

◊ **Син дә мин, Мөхәммәтәмин** — һәр кеше, теләсә кем, барыбыз да. *Аларга син ни, мин ни, Мөхәммәтәмин ни — бар да бер.* Н. Исәнбәт.— *Яшәүгә, ашауга килгәндә, Хәмит тә, син дә, мин дә, Мөхәммәтәмин дә яшәрбез дә, ашарбыз да, ләкин ни эшләрбез?* К. Тинчурин. **Син күр дә мин күр** — бәрәр эш-хәлнең кинәт һәм бик тиз булып узуын аңлату өчен әйтелә. *Шуннан, син күр дә мин күр, Урәзмәт карт кинәт баеп киткән.* Ә. Фәйзи.

СИНАГО'ГА *и.* Еврей гыйбадәтханәсе. *Коперник тарафдарларын эзәрлекләү башлана. Мәчет, чиркәү, синагогаларда бу „мөртәт" исеменә бәддога укыйлар.* Г. Гобәй.

СИНГАРМОНИЗМ *и. лингв.* Сингармония закончалыгы.

СИНГАРМО'НИК *с. лингв.* Сингармониягә нигезләнгән.

СИНГАРМО'НИЯ *и. лингв.* Сүздәге сузык авазларның калынлык-нечкәлек яки иренләшү ягыннан үзара охшаш булу күренеше.

СИНГАРМО'НИЯЛЕ *с. лингв.* Сингармония нигезендә ясала торган (сүз турында).

СИНДИКАЛИЗМ *и.* Эшчеләр хәрәкәтендәге вак буржуаз оппортунистик агым: политик көрәшнең, эшчеләр сыйныфы политик партиясенең зарурлыгын кире кагып, профсоюзлар (синдикатлар) рамкасы эчендә экономик көрәш алып баруны гына таный.

СИНДИКАЛИСТ *и.* Синдикализм тарафдары.

СИНДИКАЛИ'СТИК *с.* Синдикализмга мөнәсәбәтле. *Синдикалистик карашлар. Синдикалистик стачка.*

СИНДИКАТ *и.* **1.** Промышленностьның берәр тармагындагы капиталистик монополияләрнең бер төре: товарны җитештерүдә мөстәкыйль булган предприятиеләрнең аны сату өчен төзелгән берләшмәсе.

2. Берничә капиталистик банкның берәр зур эш (мәсәлән, заем, акцияләр һ. б. ш. чыгару) өчен төзелгән кыска вакытлы берләшмәсе.

3. Франция һ. б. кайбер буржуаз илләрдә: профсоюз.

4. 1922—1930 елларда СССРда: товарны күпләп сату, чимал хәзерләү һ. б. ш. мәсьәләләрне хәл итү өчен берәр промышленность тармагындагы берничә трестны берләштергән хуҗалык оешмасы.

СИНДИКАТЧЫ *и.* Синдикат (1, 2 мәгъ.) члены; аны оештыручы. *Россия синдикатчылары. Нефть синдикатчыларының зур табыш алуы.*

СИНЕ'КДОХА *и. махс.* Предметның үзе урынына аның берәр кисәген, өлешен яки киресенчә атап, күплек урынына берлек саны кулланып сурәтләүгә нигезләнгән стилистик алым. || Шул алым белән төзелгән сәнгатьчә троп (сүз яки тәгъбир). *Сөйләмдә синекдохалар куллану.*

СИНКО'ПА *и. лингв.* Сүз уртасында аваз (яки аваз-лар) төшеп калу күренеше.

СИНКРЕТИЗМ *и. кит.* Берәр нәрсәнең башлангыч, үсмәгән-җитлекмәгән чорына хас бүленмәгән-аерымланмаганлык, тармакланмаганлык хәле һәм күренеше. *Борынгы фәннең синкретизмы.* □ *Синкретизм, укмашканлык — бер дә җитлегү билгесе түгел, бәлки сәнгатьнең башлангыч чоры өчен хас күренеш.* Каз. утл.

СИНКРЕ'ТИК *с. кит.* Синкретизмга нигезләнгән. *Синкретик фикерләү. Синкретик сәнгать.*

СИНОД *и.* Революциягә кадәрге Россиядә: рус православие чиркәвенең иң югары коллегиаль органы; хәзер: патриарх каршындагы, киңәш бирү хокукы булган орган.

СИНО'НИМ *и. лингв.* **1.** Аваз составы үзгә, әмә мәгънәләре бердәй яки якын булган сүз, идиома һ. б., мәсәлән: „шатлык", „куаныч"; „күз ачып йомганчы", „әһ дигәнче".

2. *с. мәгъ.* Аваз составы үзгә, әмә мәгънәләре бердәй яки якын (сүзләр, идиомалар һ. б. ш. турында); синонимик. *Синоним сүзләр. Синоним тәгъбирләр.*

СИНОНИ'МИК *с.* **1.** Аваз составы үзгә, әмә мәгънәләре бердәй яки якын (сүзләр, идиомалар һ. б. ш. турында). *Синонимик сүзләр һәм сүзтезмәләр. Грамматикадагы синонимик чаралар.*

2. Синонимнардан (1 мәгъ.) тора торган, шуларны эченә алган. *Синонимик ояга кергән сүзләр. Синонимик сүзлек.* || Синонимлыкка һәм синонимикага мөнәсәбәтле. *Синонимик күренеш. Синонимик категория. Синонимик тикшеренүләр.*

СИНОНИ'МИКА *и. лингв.* **1.** Тел фәненең синонимнарны тикшерә-өйрәнә торган тармагы.

2. *җый.* Телнең барлык синонимнары; синонимнар байлыгы. [*К. Насыйри*] *татар теленең үз синонимикасын, үзенең образлы тәгъбирләрен активлаштыра.* Ш. Рамазанов.

СИНОНИ'МИЯ *и. кит. к.* синонимлык.

СИНОНИ'МЛАШУ *ф.* Синонимга яки синонимнарга әйләнү; синонимик мөнәсәбәткә керү. *Сүзләрнең синонимлашуы.*

СИНОНИМЛЫК *и.* Синоним булу күренеше, хәле. *Сүзтезмәләрнең синонимлыгын тикшерү. Синонимлык билгесе.*

СИНО'ПТИК I *и.* Синоптика белгече, һава хәлен күзәтү һәм билгеләү хезмәтендә эшләүче. *Һаваларның торышы белән синоптиклар кебек таныш булырга тиешбез.* Г. Галиев.

СИНО'ПТИК II *с.* Синоптикага мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Синоптик карта. Синоптик мәгълүматлар.*

СИНО'ПТИКА *и. махс.* Метеорологиянең һава хәленә йогынты ясаучы физик күренешләрне өйрәнүгә багышланган тармагы. || *җый.* Һава хәлен күзәтү һәм билгеләү хезмәте; шул хезмәтне башкаручылар.— *Капитан, барометр аска төшә, шторм булыр, ахрысы. Бәлки, гаваньга кайтырбыз.— Юк, синоптика шторм турында хәбәр итмәде бит.* Р. Батуллин.

СИНО'ПТИКЛЫК *и.* Синоптик һөнәре һәм хезмәте. *Бик күп еллар синоптиклыкка укыган берәү туган авылына кайтырга чыккан ди.* [*Юлда кунарга керткән*] *хуҗасы моннан: — Иртәгә һава нинди булыр икән? — дип сораган.* Г. Бәширов.

СИНТА'ГМА *и. лингв.* Бер яки берничә сүздән төзелеп, интонация һәм мәгънә ягыннан бер бөтен тәшкил иткән синтаксик бөрәмлек.

СИНТА'КСИК *с. лингв.* Синтаксиска мөнәсәбәтле. *Җөмләне синтаксик яктан тикшерү. Синтаксик*

чаралар. Синтаксик күнегүләр. Җөмләдәге сүзләрнең үзара синтаксик мөнәсәбәтләре.

СИ'НТАКСИС *и.* **1.** Грамматикада: җөмләне, җөмлә төзү өчен кулланыла торган тәгъбирләрне (мәсәлән, сүзтезмәләр һәм идиомаларны), җөмлә кисәкләренең үзара бәйләнеш ысулларын, чараларын тикшерүгә багышланган тармак. *Институтта синсаксис укыту.*

2. Җөмләнең һәм тәгъбирләрнең грамматик төзелеше, җөмлә кисәкләренең үзара бәйләнеш ысуллары һ. б. ш. *Язучы синтаксисының үзенчәлекле булуы. Катлаулы һәм авыр укылышлы синтаксис белән язылган роман. Көнкүреш сөйләме синтаксисының гадирәк булуы.*

СИНТАКСИСТ *и.* Синтаксис (1 мәгъ.) белгече.

СИ'НТЕЗ *и.* **1.** Фәнни тикшеренүнең бер ысулы: предметны бөтенлекле рәвештә һәм үзара бәйләнештәге кисәкләре-өлешләренең берлеге сыйфатында тикшерүдән гыйбарәт; *киресе:* анализ. || *кит.* Кушу-берләштерү, гомумиләштерү күренеше һәм нәтиҗәсе. *Теория белән практиканың синтезы.*

2. *хим., физ.* Химик һәм физик юл белән гади матдәләрне, элементларны кушып-җыеп катлаулы кушылма ясау, гадиләрне кушып катлаулы нәрсә булдыру күренеше һәм ысулы.

СИНТЕЗЛАУ *ф.* **1.** Синтез (1 мәгъ.) ысулы белән тикшерү; кушып-берләштереп гомумиләштерү. [*Яшьләр*] *кеше тормышына, чынбарлык күренешләренә анализ ясыйлар, ләкин шуларны синтезламыйлар.* Сов. әд.

2. Синтез (2 мәгъ.) юлы белән барлыкка китерү, ясау, табу. *Ясалма буяуларны синтезлау. Май синтезлау. Ак төсне синтезлау. Витаминнарны синтезларга өйрәнү.* □ *Бу матдәне синтезлаган лабораторияне гаепләп чыгалар иде.* А. Тимергалин.

СИНТЕЗЛАШТЫРУ *ф. к.* синтезлау.

СИНТЕ'ТИК *с.* **1.** Синтезга (1 мәгъ.) нигезләнгән. *Фәнни тикшерүнең синтетик методы.*

2. Синтез (2 мәгъ.) нәтиҗәсендә һәм ярдәмендә булдырылган, ясалма. *Синтетик сүс. Синтетик кәгазь. Синтетик ягулык. Нефтьтән меңнәрчә төр синтетик әйбер эшләү.* □ *Синтетик паркет аяк баскан тавышларны йота йотуын, ләкин тәмам бетереп җиткерми.* А. Тимергалин. *Синтетик каучук заводына бардык, аның белән танышканнан соң ясалма күн заводы цехларында булдык.* А. Расих.

3. *лингв.* Сүз формасы турында: шул бер сүзнең үзеннән генә гыйбарәт, ярдәмлек сүздән файдаланмый ясала торган; гади. *Фигыльнең синтетик заман формалары.* || Грамматик мәгънәләрне сүзнең синтетик формалары ярдәмендә белдерүгә нигезләнгән. *Синтетик һәм аналитик телләр. Синтетик юл белән ясала торган чагыштыру сыйфатлары.*

4. *лингв.* Тел берәмлекләренең үзара бәйләнеше турында: грамматик мөнәсәбәтләрне ярдәмлек сүзләрдән файдаланмыйча белдерүгә нигезләнгән. *Синтетик бәйләнеш. Синтетик төзелешле кушма җөмлә.* || Шундый бәйләнешләрне гамәлгә ашыру өчен хезмәт итә торган. *Җөмләләрне бәйләүдә синтетик алымнан файдалану. Синтетик чаралар.*

СИНТЕ'ТИКА *җый. и.* Химик синтез ысулы белән табылган материал һәм шул материалдан эшләнгән әйберләр. *Синтетика кибете. Синтетикадан эшләнгән товарларның елдан-ел артуы.* □ *Синтетикадан менә дигән йортлар салалар.* Чаян.

СИ'НУС *и. мат.* Почмакның бер тригонометрик функциясе: туры почмаклы өчпочмакта каршы як катетның гипотенузага чагыштырмасына тигез.

СИНУСО'ИДА *и. мат.* Почмак үзгәрүенә бәйле рәвештә синусның үзгәрүен күрсәтә торган, дулкын сыман кәкре сызык.

СИНХРОН *с. махс.* Бер үк вакытта була яки башкарыла торган. *Синхрон күренеш. Синхрон тәрҗемә.* || Синхрониягә нигезләнгән. *Синхрон машина. Синхрон генератор. Тел фәнендәге синхрон метод.* || Синхрониягә мөнәсәбәтле. *Тел күренешләрен тикшерүнең синхрон аспекты.*

СИНХРОНИЗА'ТОР *и. техн.* Хәрәкәтләрне тапшыра торган тешле тәгәрмәчләрнең, механизмнарның, электр машиналарының һ. б. ш. эшендә хәрәкәтләрне вакыт ягыннан бергә туры китерү җайланмасы, аппараты. *Автомобиль синхронизаторы. Электр машинасы синхронизаторы.*

СИНХРО'НИК *с. к.* синхрон.

СИНХРО'НИЯ *и.* **1.** *махс.* Ике яки берничә эшхәлнең, процессның, хәрәкәтнең бер үк вакытта булу яисә башкарылу күренеше.

2. *лингв.* Телнең үсешен түгел, бәлки аерым бер чорга хас торышын һәм системасын гына алып тикшерү методы; *киресе:* диахрония.

СИНХРОФАЗОТРОН *и. физ.* Корылмалы кисәкчекләр хәрәкәтен тизләтү җайланмаларының бер төре.

СИ'НЬКА *и.* Тукыма, кәгазь һ. б. нәрсәне зәңгәрли торган буяу.

СИНЬКАЛАУ *ф.* Синька белән зәңгәрләү. *Бөтен өйләрдә ут сүнгәч, ут тик бер өйдә генә балкый, аның бер тәрәзәсендә, сыек синькаланган үтә юка пәрдә артында яшел абажур төсмерләнә иде.* Г. Гобәй.

СИНЬКАЛЫ *с.* Синька катнаштырылган, синька салып аралаштырылган; синька белән зәңгәрләтелгән. *Синькалы буяу.* □ *Күк йөзе шундый зәңгәр, аны яңа гына синькалы су белән юып төшкәннәр төсле.* Г. Гобәй.

СИНЬОР *и.* Италиядә: әфәнде.

СИОНИЗМ *и.* XIX йөз ахырында төрле илләрдәге еврей буржуазиясе арасында барлыкка килгән реакцион буржуаз милләтчелек хәрәкәте.

СИОНИСТ *и.* Сионизм тарафдары.

СИОНИ'СТИК *с.* Сионизмга мөнәсәбәтле. *Сионистик оешма.*

СИПКЕЛ *и.* Тәндә, күбесенчә биттә булып, бигрәк тә яз һәм җәй ныкбеленә торган саргылт яки коңгырт тимгелләр яисә шуларның берсе. *Биткә куе сипкел чыгу.* □ *Гөлзәбәр вак-вак сипкел төшкән озын бармаклары белән әледән-әле бил каешын рәтли.* Г. Бәширов. *Ялангач симез беләкләренә сипкел төшкән секретарь ханым начальникка кирәкле кешеләрне чакыра тора.* Ә. Еники.

СИПКЕЛЛЕ *с.* Тәнендә сипкелләре булган. [*Газизә*] *йортның түрендә балалар белән уйнап йөрүче ябык кына, сипкелле бер малайны чакырып алды.* Ә. Фәйзи. *Ул сипкелле озын кулларын чайкап җибәрде.* А. Шамов.

СИПКЕЛЛЕЛӘНҮ *ф. к.* сипкелләү.

СИПКЕЛЛӘҮ *ф.* Сипкеллегә әйләнү. *Бит сипкеллә.*

СИПКЕЧ *и.* Сыеклыкларны бөркеп сибә, сиптерә торган махсус җайланма яки шундый җайланмалы чиләк һ. б. ш. савыт. *Яшелчәләргә сипкеч белән су сибү. Агу сипкеч.* || *неол.* Бөртекле нәрсәләрне таратып сибә торган җайланма яки шундый җайланмалы аппарат, механизм, машина. *Нинди генә машиналар кайтмый! Яшелчә утырту машиналары, ашлама сипкечләр, печән чабып җыю машиналары...* Р. Төхфәтуллин.

СИПЛӘҮ *ф.* **1.** Тузган-искергән һ. б. ш. җиренә яңа әйбер, материал куеп, төзәтү, ремонтлау (гадәттә өйне, каралтыны). *Мунча сиплә.* □ *Егет, фермага җитәрәк, берәүнең өй сипләргә китергән бүрәнәләре өстенә утырып, бию көе уйнарга кереште.* Ш. Бикчурин. *Бер көнне безнең коебызга үрдәк балалары*

егылып төшкән иде. Иртән торуыбызга коебызның бурасын сиплэп, биегэйтеп куйганнар. Г. Галиев.

2. *диал.* Ямау; баш сабып һ. б. ш. рәвештә өлешчә яңарту. *Дни бүрекне сиплэп җибәрде. Яңа оек бәйлэтеп бирделэр.* М. Гафури. *Аларның улларын мин мәктәбемә үз ризалыклары белән алдым. Аягына юк иде, үземнең иске читегемне сиплэп бирдем.* Ә. Фәйзи.

СИП-СИМЕЗ *с. Артык. дәр. к.* симез.

СИП-СИРӘК *с. Артык. дәр. к.* сирәк (1—3 мәгъ.). *Миннәт мыегын мыек дип атап булмас иде. --- Үзе сап-сарыдыр, үзе сип-сирәктер.* А. Расих.

СИПТЕРГЕЧ *и.* Сыеклыкларны бөркеп сиптерә торган махсус җайланма яки шундый җайланмалы чиләк, савыт, машина. *Урамга су сибә торган машинаның сиптергече.* □ *[Бакча] сукмагында сиптергеч күтәреп баручы Ханзафар күренде.* Р. Батуллин.— *Безгә әнә буяу сиптергеч машина кирәк.* Г. Ахунов.

СИПТЕРТҮ *ф. к.* сиптерү. *Балалардан яшелчәгә су сиптертү.* □ *— Үзең яратканны уйна! — Күңелләрәкне сиптерт, абый!* Э. Касыймов.

СИПТЕРҮ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* сибү (1—4, 7 мәгъ.).

2. Төрле җайланмалар, сиптергечләр белән сибү, бөркү. *Шланглар аркылы миллиардларча тамчылар сиптереп, җилэк түтэлләрен, җимеш куакларын коендырабыз.* Г. Галиев. *Парикмахер: — Одеколон сиптеримме? — ди.* Г. Бәширов.

3. *күч.* Берьюлы күп коралдан яки дәвамлы рәвештә көчле ату. *Автоматтан сиптерү.* □ *Акларның батареясы --- обоз өстенә шрапнель сиптерә башлады.* Ш. Усманов. *Батальоннарның беренче залплары артыннан ук пулеметлар сиптерә башлауга, дошман кавалериясе --- бик азга гына югалып калды.* И. Туктар.

4. *күч.* Бик яхшы, оста, җитез сөйләү, җырлау, бию, уен коралын уйнау һ. б. ш.— *Сөйлә давай, сиптер!* К. Нәҗми. *Солдатлар шундый шаяннар, --- авыз гармунында сиптерәләр, кызлар белән шаяралар.* А. Гыйләҗев.

СИРАТ: сират күпере — динчеләр телендә: җәһәннәм уты өстеннән оҗмахка үтә торган, кеше ышанмастай тар күпер. **Сират кичү, сират күпере кичү** — зур һәм хәвефле кыенлыкларны үтеп чыгу турында. *Бәби табучы хатын сират күпере кичә диләр.* Сөйләмнән.

СИРЕ'НА I *и.* Көчле авазлы сузынкы сигнал бирә торган аппарат, җайланма; кискен һәм улауга охшашлырак сузынкы гудок сигналы. *Һава һөҗүме вакытындагы сирена. Янгын машиналарының сиренасы.* □ *Сиренасын улатып, үзйөрешле зур баржа узды.* А. Расих. *Ашыгыч ярдәм машинасы --- сиренасын улатып юл сорый-сорый китеп барды.* Н. Дәүли.

СИРЕ'НА II *и.* **1.** Грек мифологиясендә: хатын-кыз башлы кош сурәтендәге диңгез заты (матур җырлавы белән диңгезчеләрне һәлакәтле урыннарга алдап кертә торган булган).

СИРЕНЬ *и. бот.* Аксыл шәмәхә яки ак чәчәк ата торган, куе яшел һәм шома яфраклы декоратив куак. *Өй артында сирень үстерү. Парктагы сирень аллеясе.* □ *Хуш ис бөркеп сирень чәчәге.* М. Хөсәен.

СИРИЯЛЕ *и.* Сирия халкы вәкиле.

СИРОП *и. махс.* Куе шикәр суы. || Җиләк-җимеш суына шикәр кушылган татлы сыекча.

СИРОПЛАУ *ф.* Сироп катнаштыру. *Газировщицаларга беркайчан да юл куймыйм мин. Белэбез, дим, ничек сироплавыгызны! Тиешлесен тутырып сал, дим!* Чаян.

СИРОПЛЫ *с.* Сироп кушылган, шуны катнаштырып ясалган, хәзерләнгән. *Сироплы сү эчү.*

СИРПҮ *ф.* **1.** Җиңелчә кагу, селкү-җилпү (канатны, керфекне һ. б. ш.). *Каш сирпү.* □ *Бөдрә чәчен артка сирпеп Кыз да куанып көлэ.* Ф. Кәрим. *Ул, керфекләрен еш-еш сирпеп, азрак көлемсерәп килэ.* Г. Бәширов. *Канатларын сирпеп яңадан һавага күтәрелде [кош].* И. Гази. || *Җиңелчә сугып-бәреп, орындырып алу. [Малайлар] бакча рәшәткәләрен чыбык белән сирпеп үттеләр.* Г. Гобәй.

2. Чәчү, тарату, сибү (нурны, тузанны һ. б. ш.). *Аяз күктән ай күзәтеп йөри, Төн өстенә сирпи якты сын.* Ф. Кәрим. *Җил, җир өстендә яткан салкын тузанны күтәреп, юлчыларга сирпи.* А. Шамов. || Бөркү, тарату, аңкыту (исне һ. б. ш.). *Чәчәкләр Хәятка карап көләләр һәм әллә кай җирләреннән генә аның борынына берничә исне берьюлы сирпеп торалар иде.* Ф. Әмирхан.

3. *күч.* Хисне, халәтне сиздерү, белдерү (тавыш, караш, мөгамәлә һ. б. ш. турында). *Салкынлык сирпи торган елмаю.* □ *Габдулла ул кызның үзенә бер төрле ягымлылык сирпеп көлгән тавышын ишетеп калган иде.* Ф. Хөсни. *[Кызның] шуклык, наянлык сирпегән күзләре аңа текәлде.* Ш. Хөсәенов.

4. Саркып килеп чыгу (кан һ. б. ш. турында). *[Батырханның] башы, яңаклары, муеннары ак белән бәйләнгән, берничә җирдән аз гына кызарып кан сирпеп тора.* Г. Ибраһимов.

СИРТМӘ *и.* **1.** Кое баганасына аркылы беркетеп, алгы башына чиләк, койрыгына авыр нәрсә тагылган су алу-күтәртү җайланмасы, юан колга. *Киң авызлы зур чиләк тагылган озын чылбырын асып, мәгърур рәвештә кое сиртмәсе тора. Ул авыр тимерле юан башы белән җиргә таба, ак һәм озын чылбырлы нечкә башы белән күккә таба караган. --- Аны имән багананың ике чаты аркылы үткәрелгән юан тимер күтәреп тора. --- Никадәр гади итеп эшләнгән, ә үзе коедан су алуда иң ышанычлы корылма.* Г. Галиев. *Зәйнәп апа ашыгып коега тартты Зәңгәр чиләк таккан сиртмәне.* Н. Баян.

2. Тарантас ясау һ. б. ш. өчен махсус эшләнгән, сыгылмалы нечкә колга, җепсә. *Тарантасның берәр сиртмәсе сыну.* || Колгалар-җепсәләр тезеп ясалган тарантас арбасы һ. б. ш. *Илгизәр туры кашканы тарантас сиртмәсенә җигеп капка янына китерде.* Г. Бәширов. || *диал.* Тарантас. *Сабантуйга барганчы урамда хәрәкәт кызулана; сиртмәләргә төялеп, чатыр чабып инде китә дә башлыйлар.* М. Мәһдиев.

3. Бишек элеп тирбәтү һ. б. ш. өчен булган сыгылмалы нечкә колга; силә. *Кабыктан ясап бирделәр безгә дугалы бишек, Миләш сиртмәгә элделәр, бауны юкәдән ишеп.* З. Нури. *Ачык өсле учак чокырындагы тимерләрне кыздыру өчен бер ягы түшәмдәге сиртмәгә бау белән тагылган, төп ягы аяк басып тирбәтә торган такта кисәгенә беркетелгән --- өрдергечне күргәч [Гәрәй] аптырап калды.* К. Нәҗми.

СИРТМӘЛЕ *с.* **1.** Сиртмәсе (1 мәгъ.) булган, сиртмә белән эшләнгән (кое һ. б. ш. турында). *Сиртмәле кое янында бер төркем агай-эне боз каткан улаклардан ат эчереп торалар.* И. Гази.

2. Пружинлы. *Ул сиртмәле караватын шыгырдатып әледән-әле әйләнгәләп ятты.* Н. Фәттах. *[Хәмидә] сиртмәле диванга йөзтүбән егыла.* М. Әмир.

СИРТМӘЛЕК *и.* Сиртмә материалы, агач. *Карама төбенә әти килеп Карап торган имеш, шикләнеп. Тик карама аны читләтмәгән.— Мә балаңа, дигән, сиртмәлек.— Шул сиртмәдә үстем тирбәлеп.* М. Сөндекле.

СИРӘГӘЮ *ф.* **1.** Сирәк (1 мәгъ.) булып калу. *Чәч сирәгәю. Урман авызында агач сирәгәю.* □ *Авыл сирәгәеп, балалар кими төшкәч, иске мәктәп бинасын [кечерәйткәннәр].* Каз. утл. *Бер-берсенә каршы атакага килүчеләрнең сафлары шактый сирәгәйде.* М. Гали.

2. Тыгызлыгы-куелыгы кимү, сыеклану (һава һ. б. ш. турында). [*Очучы:*] *Югары күтәрелгән саен, һава сирәгәя һәм басымы азая.* С. Баттал.

3. Булуы-үткәрелүе кимү, әзәю. *Көз ахырына таба аяз көннәрнең бик сирәгәюе. Кичке уннан соң трамвайлар сирәгәю. Юл өзегендә авылда кино сирәгәю. Хатлар сирәгәю.* □ *Икебез ике җирдә эшләгәнлектән, безнең Мирхәйдәр белән очрашуларыбыз сирәгәйде.* Каз. утл. *Бәйрәмнәр сирәгәя бара иде.* Ш. Усманов. || Аз калу, кимү. *Сугыштан соңгы елларда затлы нәрсәләрнең сирәгәюе. Сирәгәйгән спорт командасын тулыландыру.*

СИРӘК *с.* **1.** Үзара гадәттәгедән ераграк, зуррак ара калдырып урнашкан нәрсәләрдән яки кисәкләрдән тора торган; еш түгел. *Сирәк теш. Сирәк рәшәткә. Сирәк чәч. Сирәк кылыч.* || *гадәттә күплектәге исем янында.* Бер-берсеннән гадәттәгедән ераграк урнашкан; еш түгел, куе түгел, күп түгел. *Сирәк агачлы парк. Тундрада шәһәрләрнең сирәк булуы. Киттән үк күренә торган сирәк йолдызлар. Сирәк ботаклы агач. Сирәк сызыклы кәгазь.* □ [*Дүләнәнең*] *ботакларында сирәк кенә чәнечкеләре бар.* М. Шабаев.

2. Тыгыз түгел, еш түгел (тукыма һ. б. ш. турында). *Сирәк тукыма. Сирәк челтәр.*

3. *сир.* Тыгыз түгел, сыек (һава һ. б. ш. турында). *Тау һавасының сирәк булуы.* □ *Сирәк кенә зәңгәр томан аша күренеп калган кояш шикелле, Мин очратам сине...* М. Җәлил.

4. Күп очрамый торган; аз. *Сирәк минераллар. Сирәк азык.* □ *Синең кебек уңган кызлар Бу дөньяда бик сирәк.* А. Әхмәт. *Һәр футбол матчына газеталар битендә даими рәвештә бәя бирелеп килә, әмма сирәк китаплар гына җитди рецензия алу бәхетенә ирешә.* Каз. утл. *Кызны ирексезләп кияүгә бирү хәзер бик сирәк.* Сөйләмнән.

5. Гадәттәгедән озаграк вакыт арасы калдырып, озаграк торып үткәрелә-була торган. *Сирәк мәҗлесләр. Сирәк ярышлар.* □ *Кемнеңдер тыш яктан сирәк, ләкин куәтле адымнар белән якынайганы беленде.* Г. Ибраһимов.

6. *рәв. мәгъ.* Сирәк (1 мәгъ.) булып яки сирәк итеп. *Бәрәңгенең сирәк тишелүе. Агачны сирәк утыртту.* || Сирәк (4, 5 мәгъ.) хәлдә, сирәк очракта. *Олыгая башлагач спорт ярышларына сирәгрәк катнаша башлау. Ял вакытында иптәшләрне сирәк күрү.*

СИРӘКЛӘГЕЧ, СИРӘКЛӘТКЕЧ *и.* Сирәкләү әйбере, җайланмасы, коралы. *Механикалаштырылган юл белән сирәкләү культиваторлар, рәтләрне буйга сирәкләгечләр, тырмалар ярдәмендә башкарыла* [*чөгендер игүдә*]. Соц. Тат.

СИРӘКЛӘНДЕРҮ *ф. к.* сирәкләү (1 мәгъ.). *Һаваны сирәкләндерү.* □ *Түтәлләргә су сибү, үсемлекләрне утау, сирәкләндерү эше өзлексез кайнап тора.* Ш. Камал.

СИРӘКЛӘНҮ *ф. к.* сирәгәю. *Җәй ахырына сипкелләр сирәкләнү. Газларның сирәкләнүе. Көзгә таба пароходлар сирәкләнү. Урманнар кимегән саен ертыкчларның сирәкләнүе. Дини йола буенча үткәрелә торган бәйрәмнәрнең, аулак өйләрнең сирәкләнүе.* □ *Яфракларын очырып сирәкләнеп калды* [*урман*]. Г. Бәширов. *Безнең чәчләр, бәлки, сирәкләнәр; Ләкин, дуслар белән утырып, Без эчәрбез яшәү ширбәтләрен.* Ә. Ерикәй.

СИРӘКЛӘТҮ *ф.* Сирәк (1—3, 5 мәгъ.) итү, сирәккә әйләндерү. *Суган сирәкләтү. Телевизор алгач клубларда кино карауны сирәкләтү.* □ *Мин мәдрәсәгә йөрүне бик сирәкләттем.* М. Гафури.

СИРӘКЛӘҮ *ф.* **1.** Сирәк (1—3 мәгъ.) итеп калдыру, сирәккә әйләндерү. *Утыртма читәнне сирәкләү.* □ *Чөгендер тишелеп чыгып берникадәр өскә калка башлагач, куерак күренгән урыннарны кул белән йолкып, сирәкләп чыгалар.* Г. Латыйп. *Хуҗа кура агачларын сирәкләп йөри иде.* А. Расих.

2. Сирәгәю, сирәкләнү (хат-хәбәр һ. б. ш. турында). *Ерак юлга чыккан диңгезченең хатлары сирәкләү.*

СИРӘК-МИРӘК *с.* **1.** *к.* сирәк (1, 4, 5 мәгъ.).

2. *рәв. мәгъ. к.* сирәк (6 мәгъ.). *Авылның төрле урыннарында сирәк-мирәк кенә, иренеп кенә өтләр өргәләп ала.* А. Шамов.

СИСКӘНҮ *ф.* Кинәт булган борчу (курку һ. б. ш.) тойгысыннан яки кичерешеннән кискен калтыранып кую. *Куркынычның бик якын икәнен абайлап күңелдән сискәнеп киттү.* □ *Кинәт ишетелгән бу тавыштан сискәнеп артыбызга борылдык.* М. Әмир. *Сәлим шундый каты кычкырды — Акбүз дә куркып сискәнеп куйды.* Г. Гобәй.

СИСКӘНҮЛЕ *с.* Сискәнүне чагылдыра-белдерә торган, сискәнүдән барлыкка килгән (караш, хәрәкәт һ. б. ш. турында). *Муса, чәчләре үрә торгандай, сискәнүле караш белән аңа текәлде.* Ш. Маннур.

СИСТЕ'МА *и.* **1.** Чынбарлык нәрсәләренең үзара бәйләнеш һәм бәйлелек челтәрендәге әзлекле тәртип. *Табигатьнең системасын ачкан галимнәрне диннең дошман күрүе. Фикерләрне системага салу.* || Төрле эшләрнең, чараларның оештырылу тәртибе, үткәрелү рәвеше. *Тәрбия системасының төрле җәмгыятьтә һәм төрле сыйныфларда төрлечә булуы. Дәвалау системасы. Физик күнегүләр системасын үзгәртү. Олимпия системасы буенча үткәрелә торган шахмат ярышы. Төрле илләрнең сайлау системалары.*

2. Бөтендәге өлешләр-кисәкләр, элементлар бердәмлегенең гәүдәләнеше һәм чагылышы булган төзелеш, структура. *Кан әйләнеше системасын күрсәткән схема. Телнең номинатив, грамматик, стилистик, орфоэпик яки орфографик системасы. Кояш системасын өйрәнү.*

3. Аерым билге яки билгеләр нигезендә берләштерелә торган нәрсәләр җыелмасы. *Химик элементларның периодик системасы. Үлчәү берәмлекләре системасы. Төрле дәүләтләрнең акча системалары. Сузык авазлар системасы.*

4. Иҗтимагый төзелеш формасы; строй. *Капитализм һәм социализм системалары. Колониаль системаның җимерелүе.* □ *Монда хутор, участок системасы. Йортлар киң кырларга сибелеп утырган.* Г. Гали. *Дөнья матбугаты бер-берсенә капма-каршы ике иҗтимагый системаның киләчәк үсеше перспективаларын тикшерә.* Соц. Тат.

5. Бер үзәккә буйсынган оешмалар, эш өлкәләре һ. б. ш. *Халык мәгарифе системасы. Фәннәр академиясе системасындагы һәм югары мәктәп министрлыгы системасындагы фәнни-тикшеренү институтлары. Сәүдә системасында эшләүчеләр.*

6. Техник төзелеш формасы, конструкция. *Яңа система фотоаппарат.* □ [*Шиһаби*] *төрле системадагы умарталардан һәм вак-төяк кораллардан башлап бал суырту машиналарына кадәр һәммәсен үзе ясаган.* М. Гали. *Винтовкалар бик төрле һәм иске системадагылар иде.* А. Шамов.

СИСТЕМАЛАШТЫРУ *ф.* Системага (1 мәгъ.), тәртипкә китерү.

СИСТЕМАЛАШУ *ф.* Системалы тәртипкә килү.

СИСТЕМАЛЫ *с.* Системасы булган, системалаштыруга нигезләнгән; тәртипле. *Системалы белем. Системалы караш.*

СИСТЕМАСЫЗ *с.* Системасы булмаган, системалаштыруга нигезләнмәгән; тәртипсез.

СИСТЕМАСЫЗЛЫК *и.* Системасыз, тәртипсез булу хәле, күренеше. *Семья минем тормыштагы һәм*

эштәге плансызлыгымны, системасызлыгымны, тәртипсезлегемне һәм җитди түгеллегемне бетерер. М. Җәлил.

СИСТЕМА'ТИКА *и. кит.* Классификацияләү, төркемләү тәртибе; зуррак, киңрәк күләмле система. *Үсемлекләр систематикасы. Хайваннар систематикасы.*

СИТРО *и.* Алкогольсез эчемлек: җимеш суы. *Зур вокзал гөр килә. Д поездлардан яңадан-яңа халык төшә. --- Эчемлек киоскларында нарзан, ситро, газлы су җитешми.* И. Гази.

СИТСЫ *и.* 1. Тоташтан бер төсле яки бизәкле киҗе-мамык тукыма. *Аклы ситсы зат була дип Казаннан алдырмагыз.* Җыр. [*Алмабикә*] *өстенә яшел бизәкле ситсыдан тегелгән яңа күлмәк кигән.* М. Әмир.

2. *с. мәгъ.* Ситсыдан тегелгән, эшләнгән. *Ситсы яулык. Ситсы алъяпкыч.* □ *Бибинең өстендә ике кат итәкле ситсы күлмәк.* Г. Камал.

СИТУА'ЦИЯ *и. кит.* Төрле шарт, мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә туган хәл. *Революцион ситуация. Илдәге политик ситуация.* □ [*Концлагерьдагы тоткыннар:*] *Хәзер ситуация бик кызу үзгәреп тора, бер дә көтелмәгән хәлләр килеп чыгуы мөмкин.* Г. Әпсәләмов. [*Ректор — Рәхимгә:*] *Аңлагыз: шундый ситуация килеп чыкты — Сез хәзер бездән китәргә тиеш.* А. Расих.

СИ'ФИЛИС *и.* Йогышлы венерик авыру.

СИФОН *и.* 1. Аударылмый торган биек савыттагы сыекчаны агызып алу өчен кулланыла торган бормалы көпшә. *Җир сугару сифоннары. Эрегән металлны төрле савытларга таратып сала торган сифон.*

2. Шундый көпшәле яки авызлы махсус (газлы яки минераль суларны саклый торган), гадәттә шешә сыманрак савыт. *Шәһәр читенә чыкканда сифон белән газлы су алу.*

СИХЕР *и.* 1. *миф.* Әкияткә, дингә һәм хорафатларга ышанучыларча, табигать законнары белән сыешмаган күренешләрне булдырырга ярдәм итә торган ысуллар, чаралар һ. б. ш. *Сихер белән эшләнгән эш. Сихер көче.* □ [*Фатыйма:*] *Кечкенә чагымда мине караучы хатыннарның берсе сихерче иде. Шул мине сихер эшенә өйрәтте. Мин йөз җитмеш төрле сихер өйрәндем. Әгәр дә теләсәм, мин синең шәһәреңне диңгезгә, кешеләреңне балыкка әйләндерә алам.* Мең дә бер кичә. *Карт абыстай сихер даруы эчертеп үтергән аны, дигән сүзләр дә йөргән* [*халык арасында*]. Э. Касыймов.

2. *миф.* Сихер (1 мәгъ.) көче белән барлыкка китерелә торган халәт, хәл, сыйфат. *Егет сихереннән айныды. Торып караса, ни күрсен: кычыткан арасында аунап ята.* Әкият.— *Нишлисең анда, бабакай? — Менә бу серле савытның сихерен качырам.* М. Гали.

3. *күч.* Берәр нәрсәнең яки кешенең күңелне бик тарта, нык кызыксындыра һәм кызыктыра яки яраттыра торган сыйфаты, көче турында. [*Хатын-кызларның*] *Елмаюларында да Берәр сихер бар.* М. Җәлил.

СИХЕРЛЕ *с.* I. *иск.* Сихерләү (1 мәгъ.) сәләте булган, сихер көченә буйсындыра торган. [*Бәдигылҗамал:*] *Киен, кил әле тизрәк, Ибраһимга әллә нәрсә булды. Йөрәген тотып утыра. Идәннән бер кәгазь алып укыган иде, әллә, ходаем, юк исә сихерле кәгазь булдымы?* Г. Камал. *Сихерче карчык үзенең сихерле таягын бер селтәп җибәргән икән, менә дигән патша сарае пәйда булган.* Соц. Тат.

2. *иск.* Сихерләнгән, сихер тәэсиренә дучар ителгән. *Сихерле капчык.* □ [*Сафура, кулына алтын акча алгач:*] *Кара әле, атасы, әллә нишләп алтыннар каралып киттеләр! --- Әллә нинди сихерле акчалар! Тфү-тфү!* А. Әхмәт. [*Гатау:*] *Сихерле чаршау-лармы соң ул, селкенә дә тора.* М. Фәйзи. || Сихер тәэсирендә барлыкка килгән. *Сихерле йокы.*

3. *күч.* Күңелне нык тарта, бик кызыксындыра һәм кызыктыра яки яраттыра торган. *Тамашачы халык --- моңлы җырның сихерле авазларына таң калган иде.* Г. Бәширов. [*Морат — Рәйханга:*] *Нинди мин күрмәгән яңа матурлык синдә! Нидән болай... Элекедән мең кат гүзәл, мең кат сихерлерәк син.* Н. Исәнбәт.

4. *күч.* Гадәти түгел, табигый булмаган, серле. *Сихерле тормышы Бу ике гашыйкның Кабынды мәхәббәт Утында яшьлекнең.* М. Җәлил. *Меңләп йолдыз, үзләренең фосфорлы ялтыравыклары белән төннең караңгы күгендә елтырап, җиргә сихерле яктылыклар коялар.* Ф. Әмирхан.

5. *к.* сихерче. *Батырша белән бәйләнергә дә куркалар. Имеш, аның әллә нинди сихерле карчыклары бар. Ул шулар аркылы терлекне агулый, имеш.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

СИХЕРЛӘҮ *ф.* 1. *иск.* Дингә һәм хорафатларга ышанучыларча, сихер (1 мәгъ.) ярдәмендә берәр нәрсәгә яки кешегә үзең теләгән сыйфатны бирү. [*Шахмат уйнап утыручы маймылны күргән кыз:*] *Бу бит гыйфрит сихерләгән кеше.* Мең дә бер кичә. *Бигрәк гажәп бер эш булды шунда, Өн мөкән бу яки төшме бу? Җен-шайтаннар юри эшләп киткән, Сихерләгән берәр эшме бу?* М. Гафури.

2. *күч.* Күңелне бик тарту, нык кызыксындыру һәм кызыктыру яки яраттыру. *Бу аһәңле җыр мине сихерләде.* Э. Айдар. *Кайсы икән ул? Егетне сихерләп, йокысын качырган кем кызы икән ул?* Э. Касыймов. *Китапның соңгы битләрендәге шигырьләр һәм җырлар аны бөтенләй сихерләделәр.* Ә. Фәйзи.

СИХЕРЧЕ *и. иск.* Сихерләү белән шөгыльләнүче. *Берлинда бар бер сихерче, Чәнечке йота, имеш. Утлы күмерне ялангач Кул белән тота, имеш. Күп шәһәрләрне күргән ул, Күп илләрдә булган ул. Сихере белән халыкны Гаҗәпкә калдырган ул.* М. Җәлил.

СИХЕРЧЕЛЕК *и.* Сихерче кәсебе.

СИХРИ *с.* Сихерли торган; сихерләнгән. *Сихри көч, дога, нур, караш, гөл, урман, тынлык.* □ *Ул өйләр, ул фатирлар әкиятләрдәге сихри сарайлардан бер дә ким түгел.* Р. Төхфәтуллин. *Язның безне котлап нур кылларында уйнаган, бары йөрәкләр генә ишетә торган сихри музыкасын онытылып тыңлыйбыз.* Ә. Еники.

СИХӘТ *и.* 1. Саулык-сәламәтлек өчен файдалы тәэсир. *Имән себеркесе белән чабынуның рәхәтен белмисең әле син, юларкәем! Аның җитмеш җиде сихәте бар.* Г. Әпсәләмов. *Безнең Агыйдел балыгының һәртөрле авыруларга да сихәте зур, дип кыстый торгач, Артем Семенович хәтсез генә ашап ташлады.* М. Шабай.

2. *с. мәгъ.* Сау-сәламәт. *Апа, яшьтән үк сихәт булмаганга, колхоз эшенә йөрми.* А. Гыйләҗев.

СИХӘТЛЕ *с.* Саулык-сәламәтлек өчен файдалы; шифалы. *Яңа себерке белән чабынуның тәнгә сихәтле булуы. Урманның сихәтле һавасы. Сихәтле дару.* □ *Туган җирем, беләм, сихәтле.* Ә. Юныс.

СИХӘТЛЕК *и.* Саулык-сәламәтлек. [*Әгъләм:*] *Сихәтлек хәзергә зарарсыз.* Ә. Камал. *Тәмле кымыз кемгә генә Сихәтлек китермәгән!* С. Урайский.

СИХӘТЛӘНҮ *ф.* Савыгу, сәламәтләнү. *Авырулар барысы да сихәтләнер.* И. Гази. [*Зиннәтнең*] *ул арада, бәлки, кулы да сихәтләнер, яңадан укырына китәр.* Г. Бәширов.

СИХӘТСЕЗ *с.* Сау түгел, чирле.

СИХӘТСЕЗЛЕК *и.* Сау-таза булмау хәле. *Сихәтсезлегем аркасында менә шушында торып калдым бүгай.* Ф. Хөсни.

СИШӘМБЕ *и.* Календарь атнаның икенче, дүшәмбедән соң килә торган көне.

СИЮ *ф.* Организмдагы сидекне чыгару.

СКА'ЛЬПЕЛЬ *и.* Кечкенә хирургик һ. б. ш. пычак. [*Заһит*] *кәгазь кисә торган скальпельне кулында әйләндерә-әйләндерә кашларын җыерып уйланып торды.* А. Расих.

СКАРЛАТИ'НА *и.* Күбесенчә балаларда була торган каты, йогышлы авыру (тышкы билгеләре: температура күтәрелә, тамак авырта, тәнгә вак-вак кызгылт тимгелләр чыга).

СКАФАНДР *и.* Су астына төшкәндә, галәмгә очканда һ. б. ш. очракта кия торган, сулау аппараты куеп эшләнгән махсус герметик кием. *Баткан корабларны скафандр киеп тикшерү. Космонавт скафандры.*

СКВА'ЖИНА *и махс.* Җирне бораулап ясаган тирән, тар тишек. *Вертикаль скважина. Шахталардагы горизонталь скважиналар. Авыш итеп бораулаңган скважина. Нефть скважинасы.* □ *Авылның ике очында ике тирән скважина казылган. Җил көче белән хәрәкәт итүче ике двигатель 47—48 метр тирәнлектән су күтәрә.* М. Максуд. || *сөйл.* Шул скважина һәм аның тирәсендәге (гадәттә җир өстендәге) ярдәмче корылмалар. [*Рәхимә, буровойга күрсәтеп:*] *Дһә алар барысы бергә скважина дип атала: вышка, насос машиналары, әнә ротор.* А. Әхмәт.

СКВЕР *и.* Гадәттә шәһәр җирендә: агач, куак, чәчәк кебек нәрсәләр утыртылган кечкенә җәмәгать бакчасы. *Декоратив агачлардан һәм чәчәкләрдән ясалган сквер.* □ *Тәрәзә каршындагы скверда балалар уйный.* А. Расих.

СКЕЛЕТ *и.* Кеше яки хайван гәүдәсен беректереп тота һәм аның каты үзәген тәшкил итә торган барлык сөякләр (тоташ һәм бөтен хәлдә). *Дәрестә кеше скелетын өйрәнү. Кош скелеты.*

СКЕ'ПТИК *и.* **1.** *махс.* Скептицизм тарафдары.

2. *с. мәгъ. кит.* Икеләнеп, шикләнеп караучы; ышанмаучанлык белдерүче. *Имештер, Дәүләтшинны пуля алмый аны. --- Кайберәүләр көнләшәләр, бәхете шайтанның, диләр. Скептиграклар әйтә, әҗәле җитмәгәндер әле, ди.* И. Гази. *Ни кадәр генә скептик булма, аларның көрәшкә һәм җиңүгә юнәлтелгән бу омтылышларына шикләнеп карарга яки ирония белән карарга мөмкин түгел иде.* Ф. Хөсни.

СКЕПТИКЛЫК *и.* Скептик булу хәле; шуңа хас сыйфатлар.

СКЕПТИЦИЗМ *и.* **1.** *махс.* Философиядә: объектив чынбарлыкны танып белү мөмкинлеген шик астына алып, шул карашны алга сөрүче юнәлеш.

2. *кит. к.* скептиклык.

СКЕ'РЦО *и. муз.* Җанлы, кызу темплы, кечерәк күләмле музыкаль әсәр. || Зур музыкаль әсәрнең (симфониянең, сонатаның) шундый темплы берәр кисәге.

СКЕТЧ *и. махс.* Шаян эчтәлекле кыска эстрада пьесасы.

СКИПИДАР *и.* Ылыслы агачлар сумаласыннан алына торган, зәһәр исле, төссез яки саргылт сыекча. *Газизә апа, тагын камфаралар кайнатып, скипидар исләре чыгарып, Вәли абзыйны дәвалады.* Ә. Фәйзи.

СКИПИДАРЛЫ *с.* Скипидары булган, скипидар катнаштырылган. *Киевгә көя төшмәсен өчен аңа скипидарлы нафталин эремәсе сөртергә, ә аннары ДДТ порошогы сибәргә була.* Азат хатын.

СКИФ I *и.* Безнең эрадан берничә гасыр элек Кара диңгез буеның төньягында яшәгән кабиләләр кешесе.

СКИФ II *и. спорт.* Шома итеп тышланган озын, тар ярыш көймәсе.

СКЛАД *и.* Әйбер саклый торган махсус урын, бина. *Азык склады. Кибет склады. Утын склады. Товарны складтан кибеткә чыгару.* □ *Орлык склады буенда өелеп куелган ташлар бар.* М. Җәлил.— *Ярмаларны складка бушатыгыз.* Г. Гобәй.

СКЛАДЧЫ *и.* Складта саклана торган нәрсәләр өчен материаль җаваплы һәм шунда эшләүче кеше.

СКЛЕРО́З *и. мед.* Органнардагы тукыманың тыгызланып каты бер хәлгә килүе нәтиҗәсендә барлыкка килә торган чир.

СКЛЕРО́ЗЛАНУ *ф.* Склероз чиренә тару. *Мәдинәнең колагы әтисенең нәкъ йөрәге өстенә туры килде. Мәдинә ул йөрәкнең тибүен ишетте. --- „Тузган, склерозланган йөрәк“ дип уйлап алды Мәдинә.* Ш. Хөсәенов.

СКЛЕРО́ЗЛЫ *с.* Склероз чире булган, шуның белән авырый торган. *Склерозлы карт.* □ *Бер склерозлы абзыйны анкета тутырганда үзенең исемен хәтерли алмый йөдәп беткән дип тә сөйлиләр.* Г. Минский.

СКРЕ'ПЕР *и. махс.* Балчыкны казып, күчереп яки тигезләп баручы машина. *Бер артка чигенеп, бер алга ташланып ярны сөзгән баһадир бульдозерларга --- мәйдан инде киңәя төшкәч, ярдәмгә үзбушаткычлар, скреперлар һәм бүтән төр җир казыгычлар килде.* З. Нури. *Яз җиту белән бульдозер яки скрепер кирәк булачак.* М. Шабай.

СКРЕ'ПЕРЧЫ *и.* Скреперда эшләүче.

СКРИ'ПКА *и.* Сызгыч белән уйнала торган дүрт кыллы, югары тембрлы уен коралы. *Скрипка уйнау*

СКРИПКА́ЧЫ *и.* Скрипка уйный белүче.

СКРИПКӘ *и. сөйл. к.* скрипка. *Ул айлар буе. кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде.* Ә. Еники. *Болар зиндан янына килеп җиткәндә, Алпамшаның скрипкә уйнап утырган чагы була.* Әкият.

СКРИПКӘ́ЧЕ *и. сөйл. к.* скрипкачы. *Скрипкәче ике-өч йорт узганчы яңадан шулай уйный-бии сикергәләп барды да, скрипкәсен айкап, тагын җанфәрманга кычкырып куйды:— дй, чыгызыз урамга, ишетегез! Патшаны төшергәннәр!* Г. Бәширов.

СКУ'ЛЬПТОР *и.* Скульптура (2 мәгъ.) белән шөгыльләнүче һөнәр иясе, скульптура әсәрләре иҗат итүче художник. *Кабер ташын скульптордан эшләтеп алу.* □ *Скульптор төзә, кыю төзә Ышанып ул иҗат көченә.* С. Хәким.

СКУЛЬПТО́РЛЫК *и.* Скульптор һөнәре һәм хезмәте.— *Скульпторлыкка укырга һәм өйрәнергә керештем (мин кечкенәдән үк сын әвәләп ясарга ярата идем).* С. Баттал.

СКУЛЬПТУР *с. махс.* Скульптурага мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Скульптур сыннар. Йортның скульптур бизәкләре. Образның скульптур формасы. Скульптур ансамбль.*

СКУЛЬПТУ'РА *и.* **1.** Сынлы сәнгатьнең бер төре: коеп, әвәләп яки кисеп-чукып, күләмле — өч үлчәмле форма әсәрләре иҗат итү сәнгате. *Көнчыгыш скульптурасының декоратив сәнгатькә зур әһәмият бирүе.*

2. *җый.* Күләмле — өч үлчәмле итеп, каты яки пластик (үзле) материалдан эшләнгән сынлы сәнгать әсәрләре (әсәре). *Монументаль һәм декоратив скульптура. Рельеф скульптурасы. Кеше һәм хайван скульптуралары. Борынгы скульптура үрнәкләре.* □ [*Музейда*] *күп кенә скульптуралар да күрәбез.* Г. Гали.— *Бер совет партизаны образын скульптурада гәүдәләндерү ниятe белән --- материаллар туплап йөрим.* С. Баттал.

СКУ'МБРИЯ *и. зоол.* Орчык сыманрак гәүдәле, ашау өчен аулана торган вак дингез балыгы.

СЛАВИСТ *и.* Славистика белгече.

СЛАВИ'СТИКА *җый. и.* Славян телләрен, әдәбиятын, культурасын, тарихын, көнкүрешен һ. б. тикшерә торган фәннәр.

СЛАВЯН *и.* Европа һәм Азиядә яшәүче, телләре һәм культуралары ягыннан кардәш көнчыгыш (рус, украин, белорус), көнбатыш (поляк, чех, словак һ. б.) һәм көньяк славян (болгар, серб, хорват һ. б.) халыкларыннан берсенең вәкиле.

СЛАВЯНЛАШУ *ф.* Тел һәм гореф-гадәт ягыннан славянга әйләнү.

СЛА'ЛОМ *и. спорт.* 1. Контроль маяклар (флаглар) кадалган бормалы маршрут буенча чаңгы белән таудан шуу ярышы.

2. Таулы елгалардан бер кешелек байдаркалар белән төшү ярышы.

СЛАЛОМЧЫ *и. спорт.* Слалом ярышына катнашучы, слалом остасы.

СЛА'НЕЦ *и.* Катлам-катлам төзелешле тау токымы (юка-юка катламнар рәвешендә таркатып була). *Яна торган сланец. Утырма сланец. Кристаллик сланец.*

СЛЕ'САРЬ *и.* Металл әйберләрне кулдан эшләү, җыю һәм төзәтү остасы, эшче. *Ремонтта эшләүче слесарь.* □ *Хәзерге заманда слесарь я токарь булыр өчен математиканы да, физиканы да яхшы белергә кирәк.* А. Әхмәт.— *Бу эшкә синең кулың бик ята. Нәрсә әйтсәң дә, слесарь кеше бит син.* А. Шамов.

СЛЕСАРЬЛЫК *и.* Слесарь һөнәре, вазифасы һәм хезмәте. *Һөнәр мәктәбеннән слесарьлыкка укып чыгу.*

СЛЁТ *и. кит.* Берәр массовый оешма членнарының, уртак профессия ияләренең съезды, җыелышы. *Пионер слеты. Авыл хуҗалыгы алдынгыларының слеты. Яшь туристлар слеты.*

СЛИ'ВА *и.* Каты эре төшле, аксыл шәмәхә, каралҗым яки саргылт җимеш.

СЛОВАК *и.* Чехословакия составындагы Словакиянең төп халкы вәкиле (көнбатыш славян).

СЛОВЕН *и.* Югославия составындагы Словениянең төп халкы вәкиле (көньяк славян).

СЛЮДА *и.* Катлам-катлам, үтә күренмәле, техникада кин кулланыла торган минерал.

СМЕ'НА *и.* 1. Регуляр кабатлана торган, махсус билгеләнгән эш һ. б. ш. вакыты. *Беренче сменада уку. Сменага өлгерү.* □ *Бүген кичке сменага эшкә килерсең.* И. Гази. *Бригада бер атналык эшне ике сменада эшләп ташлады.* Соц. Тат. || Шушы вакыттагы эш, хезмәт. *Сменадан бушау белән үк,* [*Мостафага*] *Иманкол хаҗиның теге яки бу йомышын арзан хакка үтәп йөрергә туры килә иде.* К. Нәҗми. *Кай арададыр салкынайтып та җибәргән. Шулай да сменаларын тапшырып урамга чыккан яшьләргә бер дә салкын түгел иде.* М. Шабай.

2. *җый.* Бер сменада (1 мәгъ.) эшләүчеләр, укучылар һ. б. ш. төркеме. *Яңа смена килгәнне көтү. Сменаңны алга чыгару өчен ярышу.* □ *Безнең сменада бары да яшьләр.* Ф. Кәрим. *Аның бригадасы --- ике норма бирә, башка сменаларны да үзенә ияртеп бара.* С. Сабиров.

СМЕНАДАШ *и.* Берәү белән бер үк сменада (2 мәгъ.) эшләүче, постта торучы һ. б. ш. *Трамвайга кереп утыргач, сменадашлар --- тирбәлә-тирбәлә кайта бирделәр.* Каз. утл.

СМЕ'НАЛАП *рәв.* Сменаларга (1 мәгъ.) бүлеп яки бүленеп, алмашлап. *Завод-фабрикада сменалап эшләү. Атларны сменалап җигү. Сменалап укыту.*

СМЕ'НАЛЫ *с.* Сменаларга (1 мәгъ.) бүлгән, сменалап башкара торган (эш, уку һ. б. турында). *Эшче яшьләрнең кичке дип тә, сменалы дип тә йөртелә торган мәктәбенә рус теле укытучысы кирәк иде.* Каз. утл. *Аның эше сменалы; кайчан буш, шул чакта уйный* [*гармунын*]. Ш. Бикчурин.

СМЕРД *и. тар.* Борынгы Русь илендә: игенче-крестьян.

СМЕ'ТА *и.* Киләчәккә планлаштырылган чыгымнар-керемнәр хисабы. *Мәктәп сметасы. Ремонт сметасын төзү. Смета чыгымнары. Авыл советы сметасында караган эшләрне үтәү.* □ *Ногман белән абзарлар салу турында сметалар төзеп утырдык.* Т. Гыйззәт. *Мондый эшкә тотынганга кадәр, берничә ел алдан чарасына керешергә кирәк, аннан соң планга кертеп смета расларга кирәк, аннан штат булдырырга кирәк.* А. Расих.

СМИ'РНО *хәрби.* Төз басып хәрәкәтсез торырга боерык бирелгән хәрби команда. *Смирно! командасы бирелгәч, саф алдына бер төркем командирлар килеп туктады.* Г. Әпсәләмов.

Смирно басу (тору) *махс.*— гәүдәне хәрәкәтсез тотып төз басу; үрә кату. *Алар, стройда смирно басып, башкаларның җырлаганнарын тыңлап тордылар.* М. Гали.

СМОТР *и.* Гадәттә тантаналы төстә уза торган рәсми тикшерү, карап чыгу. *Смотр ясау. Смотрга катнашу. Үзешчән сәнгать смотры. Хәрби смотр. Район смотры.* □ *Мин үз күзем белән күреп чыгар өчен легионны смотрга хәзерләргә куштым.* Ш. Усманов. [*Заводта*] *продукциянең сыйфатына җәмәгать смотрлары үткәрелә.* Соц. Тат.

СНА'ЙПЕР *и.* Төз ату остасы. *Сине фронтта бик мактаулы снайпер булган икән дип сөйләгәннәр иде.* А. Шамов. *Тазалыгың шәп, күзләрең дә снайпер күзләре кебек үткен.* А. Әхмәт.

СНА'ЙПЕРЛЫК *и.* Снайпер һөнәре һәм сәләте, төз ату осталыгы. *Снайперлыкка уку.* □ *Ләләне ул үзе снайперлыкка өйрәткән булганлыктан, аның уңышларына аерата мактана иде.* Г. Әпсәләмов.

СНАРЯД *и. махс.* Туптан аттырыла торган, зур пуляга охшаган шартлагыч корал. *Артиллерия снаряды. Реактив снаряд. Снаряд кыйпылчыгы тиеп яралану. Яндыргыч снаряд. Снаряд чокыры. Снаряд төшеп ярылу.* □ *Беренче снаряд артыннан икенчесе, өченчесе сызгырып узды.* И. Гази.

СОБОР I *и.* Шәһәрдә, монастырьда: төп яки зур чиркәү. *Монысы, гөмбәзе алтын белән япканы — собор, ягъни олы чиркәү була.* Фәтхи-Балыкчы.

СОБОР II *и.* 1. *тар.* Элекке Россиядә: гадәттә дәүләткүләм оештыру-идарә мәсьәләләрен карап хәл итү өчен чакырыла торган түрәләр яки вәкилләр җыелышы. *Земский собор.*

2. Югары христиан руханилары җыелышы, съезды. *Чиркәү соборы.* □ *Уналтынчы йөз урталарында соборга җыелган архиерейлар, „сергачларның бозык гадәтләреннән“* [*аю биетеп йөрүләреннән*] *зарланып, патшага хат та язганнар.* К. Нәҗми.

СОВ- Кыскартылган кушма сүзләрдә „совет“ мәгънәсендәге беренче кисәк, мәсәлән: **совхоз, Совинформбюро, Совнарком.**

СОВЕТ *и.* 1. СССР халкының дәүләт властен гамәлгә ашыра торган, сайлаулы, вәкиллекле органы. Советлар — дәүләтебезнең политик нигезе. *Авыл советы. Җирле советлар. Халык депутатлары советы. Советка сайлау. Совет сайлау системасы.*

2. *сөйл.* Советлар иле, СССР. *Совет хөкүмәте. Совет халкы.* □ *СССРның көннән-көн ныгаюы күзгә керә, Совет турындагы ялганнарның ал һәм арт яклары ачыла бара.* Г. Гали.

3. Төрле коллегиаль үзәкләрнең, органнарның исеме. *Институтның гыйльми советы. Заводның техник советы. БМОның Куркынычсызлык советы. Министрлар советы. Пионер дружинасы советы.*

СОВЕТЛАШТЫРУ *ф.* Совет власте органнары булдыру, төзү. *Илне советлаштыру чоры.*

СОВЕТЛАШУ *ф.* Совет яклы булып әверелү, совет ягына чыгу яки күчү. *Волостьларның советлашуы.*

СОВЕТЧЫ *и.* Совет яклы кеше. *Аның алдында кешеләр икегә: дуска, дошманга бүленәләр. Ихлас күңелдән советчылар — болар дуслар. Болай булмаганнар — контрлар.* Г. Ибраһимов. [*Сәләхи — Хәмидәгә:*] *Без, туганкай, сине комсомолга тартырга карар бирдек. --- Синең шикелле аңлы советчы яшьләрне үз арабызга алып комсомол тәрбиясе бирергә тырышачакбыз.* Ш. Камал.

СОВЕТЧЫЛ *с.* **1.** Совет яклы, совет тарафдары. *Совет балалар әдәбияты үзенә советчыл яңа катлау язучылар кадрын тартты, үсүгә, ныгуга табан йөз тотты.* Ф. Кәрим. *Бигрәк чын советчыл инде син, әнем. Күбрәк булсын иде андыйлар.* Р. Төхфәтуллин.

2. Совет иленә, строена хас. *Чын дуслык — безнең советчыл дуслык кирәк.* Р. Ишморат.

СОВЕТЧЫЛЫК *и.* Совет яклылык, советча караш. *Бичерман халкы — элек-электән җиргә, иген игүгә хирес халык. Тырыш. --- Әмма иң әһәмиятлесе шунда: советчылык көчле.* Э. Касыймов.

СОВХОЗ *и.* Социалистик авыл хуҗалыгында дәүләт предприятиесе; *русчасы:* советское хозяйство. *Без гигант заводлар, гигант совхозлар төзибез.* Һ. Такташ.

СОВХОЗДАШ *и.* Бер үк совхоз члены, шул үк совхоздагы кеше. *Әйткәнен эшли, үз дигәненә ирешә торган кеше ул Асия. Һәм бу юлы да аңа совхоздашлары алдында кызарырга туры килмәде.* Соц. Тат.

СОВХОЗЛАШТЫРУ *ф.* Совхоз итеп үзгәртеп кору.

СОВХОЗЛАШУ *ф.* Совхозга әйләнү, совхоз булып оешу (авыл, аның халкы турында).

СОВХОЗЧЫ *и. сир.* Авыл хуҗалыгы эшчесе: совхоз члены. *Төнге җилләр совхоз кыры буйлап Сызгырынып очып йөрделәр. Кая гына барып өрсәләр дә, Совхозчыны постта күрделәр.* М. Җәлил.

СОГЫНУ *ф. диал.* Зур-зур кабып ашау. *Күлләрдә йөзеп йортка кайткач, алар бергәләшеп бер табактан ашаганда да ул бер вакытта да үз алдыннан ашамый, муены озынлыктан файдаланып, гел каршы яктан, туганнары алдыннан алып согына, шуның өчен бәбкәләр арасында тавыш-җәнҗәл куба, кыч-кырыш китә икән.* Н. Исәнбәт.

СОʻДА *и.* Углекислый натрий тозы (техникада һәм көнкүрештә кулланыла). *Аш яки чәй содасы (ак кристаллик матдә). Кристаллик сода. Кальцийлы сода.* □ [*Нәҗия*] *әнисенә шалтыратып сорашып кына тора: --- Пылауны ничә стакан суда кайнатырга, төче бәлеш камырына күпме сода салырга? Әнисе кебек аның мактаулы аш-су остасы буласы килә.* Ә. Еники.

СОКЛАНГЫЧ, СОКЛАНДЫРГЫЧ *с.* Сокланыр дәрәҗәдә яхшы, матур һ. б. ш; сокланырга мәҗбүр итә торган. *Соклангыч күренеш. Сокландыргыч моң.* □ *Соклангыч бит безнең бу яшь гомер.* Ш. Маннур. *Суы да суы, көмеш бөртеге күк, нинди соклангыч.* М. Гали.

СОКЛАНУ *ф.* Гадәттән тыш ошатып-яратып карау. *Берәүнең зирәклегенә соклану. Батырлыкка соклану. Матур җырны сокланып тыңлау. Тату яшәүче семьяның матур тормышына соклану.* □ *Язгы саф матур гөлгә карап сокланган төсле генә, ул аңа карап сокланып торды.* К. Тинчурин. *Мин аның уйнап торган зифалыгына, күзләрне камаштырырлык чисталыгына, кайнар яшьлегенә, тиңсез матурлыгына сокланып, онытылып калдым.* М. Әмир.

СОКЛАНУЛЫ *с.* Сокланучы белдергән, соклану катнаш булган (караш һ. б. ш. турында). *Барысы да кызыксынып ниндидер сокланулы хөрмәт белән аларга карыйлар иде.* Г. Әпсәләмов.

СОЛДАТ *и.* **1.** Армиядә хезмәт итүче, хәрби дәрәҗәсе булмаган кеше. [*Шаяхмәтне*] *карт солдат дип йөртәләр. Ә бу исем һәрбер карт солдатка бирелми иде. Бу исем күпне күргән, күп сугышларда катнашкан, иле, халкы өчен батырлыклар күрсәткән олы яшьтәге солдатка хөрмәт йөзеннән әйтелә иде.* А. Әхмәт.

2. *кыек килешләрдә.* Солдат хезмәте, хәрби хезмәт. *Солдатка каралу, алыну. Солдатка озату. Солдаттан калу, кайту. Солдатта булу.* □ *Вахит үзенең солдатта йөргәндә күргән нәрсәләрен өстән генә сөйләп үтте.* М. Гафури.

3. Октябрьга кадәр: солдатта хезмәт итеп кайткан, солдат хезмәтендә булган кеше турында. *Фатиханың атасы Сәхибулла солдат, үзенең калын кара мыекларын бөтерә-бөтерә, һәрвакыт: — Дөнья куласа, әйләнә дә бер баса,— дип сөйләнергә ярата.* Ә. Фәйзи.

СОЛДАʻТКА *и. сөйл.* Ире армиядәге, солдат хезмәтендәге хатын. *Днисе Бәдига түти, ул заманның теле белән әйткәндә, солдатка Бәдига, хәзрәтләрдә хезмәтче хатын булып көн күрде: казан асты, су ташыды, кер юды.* Г. Минский. [*Мәүлиха:*] *Хәзерге солдаткалар Николай заманында без күргән азапны төшләрендә дә күрмиләр.* Г. Бәширов.

СОЛДАФОН *и. кит. кимс.* Үз хезмәте белән генә чикләнгән карашлы, тупас, культурасыз хәрби кеше. *Сез бу солдафонга әһәмият бирегез,— карт күз кырыйлары белән немецка күрсәтте.— Аның бит барлык идеалы баш булу һәм бүтән кешеләр исәбенә яшәү!* А. Расих.

СОЛИДАР *с.* Солидарлык күрсәтүче яки белдерүче.

СОЛИДАРЛАШУ *ф.* Солидарлык күрсәтү яки белдерү, солидар булу.

СОЛИДАРЛЫК *и. кит.* Берәүнең карашларын, эшчәнлеген актив яклау; теләктәшлек һәм фикердәшлек. *Бөтен дөнья хезмәт ияләренең солидарлыгы үсү.* □ *Советлар иленең коммунистлары һәм бөтен халкы буржуаз илләрнең хезмәт ияләренә кайнар солидарлык белдерәләр.* Соц. Тат.

СОЛИДОЛ *и.* Техник майлауга китә торган бер төр куе матдә.

СОЛИПСИЗМ *и. филос.* Ахыр чиккә җиткерелгән субъектив идеализм; аның раславынча, субъект (ягъни кеше) аңы гына чынбарлык булып, тышкы дөнья шуның аңында гына яши.

СОЛИПСИСТ *и. филос.* Солипсизм тарафдары.

СОЛИСТ *и. махс.* Үзе генә, ялгыз чыгыш ясаучы артист (җырчы, биюче, уен коралы уйнаучы һ. б.). *Балет цехы, аз сандагы солистлардан тыш, байтак кына өйрәнчек яшь көчләрне берләштерә; --- болар арасыннан театрның таланлы яңа солистлары үсеп чыгачак.* М. Җәлил. *Солистлар да, хор да, оркестр да, биючеләр дә спектакльгә бик күп көч куеп эзерләнделәр.* Азат хатын.

СОЛТАН *и.* **1.** Кайбер мөселман дәүләтләрендә: патша, монарх. *Бәхет-дәүләт бер сәбәпле кулдан китсә, Солтаннар балыкчыга хезмәт итәр.* М. Гафури. [*Тархан — ханга:*] *Падишаһым, солтаным! Телэгегез үтәлде!* М. Җәлил.

2. *күч.* Башкалардан бик өстен кеше турында. *Син бит егетләрнең солтаны.* Җыр. *Болгар читек, саурый башмак, Сиңдер кызның солтаны.* Н. Исәнбәт.

СОЛТАНАТ *с. иск.* Горур, мәһабәт (кыяфәт һ. б. ш. турында). *Ишек ике якка ачылды. Зур буйлы, солтанат кыяфәтле, агара башлаган чәчле байбичә килеп керде.* Г. Ибраһимов.

СОЛТАНАТЛЫ *с. иск.* Зур дәрәҗәле һәм авторитетлы. *Солтанатлы кияү.* □ *Шундый хыянәткә юл ачык Солтанатлы сарай түрендә.* Ф. Бурнаш. *Кайнап тора самовар Солтанатлы байларда.* М. Максуд.

СОЛТАНЛЫК *и.* **1.** Солтан дәрәҗәсе, исеме. [*Бирем карт:*] *Бабаларыгыз ханлык өчен, аталарыгыз солтанлык өчен, сез үзегез түрәлек --- өчен, яхшы җәйләүләрне кулыгызда калдырып, мал, дәүләт саклау өчен Сары-Арканы урыс патшага кол кылдыгыз.* Г. Ибраһимов.

2. Солтан власте, режимы; солтанга буйсынулы хөкүмәт. *Яңа хөкүмәт солтанлыкның бәреп төшерелүен --- игълан итте. Солтан һәм элекке хөкүмәт членнары илдән качтылар.* Соц. Тат.

3. Башында солтан торган ил, дәүләт.

СОЛЫ *и* **1.** Кыяклыларга керә торган сабан ашлыгы (башлыча ат азыгына һәм ярмага китә); *русчасы:* овес. *Солы җире. Солы уру. Солының җил уңаена сөрлегүе.* □ *Чүмәлә хәтле солы кибәне. Чәчүгә җитәрме, белмим...* Ш. Маннур.

2. *җый.* Шул ашлыкның орлыклары. *Яргычта солы ярдыру. Солы ярмасы.* □ *Ат печән ашаудан туктагалган, солы өмет итеп тора.* Ш. Камал.

СОЛЫЛЫ *с.* **1.** Солысы (2 мәгъ.) булган, солы салынган. *Солылы капчык. Солылы бура.* || Солы чәчелгән. *Солылы басу.*

2. Солы (2 мәгъ.) белән катышкан, аралашкан. *Солылы кибәк. Солылы фураж.*

3. Арасында солы (1 мәгъ.) булган, солы белән катыштырып чәчелгән; солы белән аралаштырылган. *Малга дигән солылы борчакны чабу.* □ *Ул трактторга тагылган вагонына солылы вика төяде.* А. Гыйләҗев.

СОЛЫХ *и.* Үзара сугышны туктату турында төзелгән килешү, договор. *Солых төзү. Солых ясау. Вакытлы солых.* □ *Совет дәүләте Ленин имзасы белән беркетелгән беренче декретында ук барлык халыкларга солых тәкъдим иткән иде.* Г. Иделле. *Солых дигәне шул килешү инде,— диде Шәрифҗан.— Килешү турында декрет кабул ителгән.* И. Гази.

СОЛЫЧА *и.* Солыга охшашлы чүп үләне; *русчасы:* овсюг. || Шул үләннең орлыгы. *Иләкләрне дөрес сайламаганнар. Машинадан үткәрелгән бодайда солыча һәм башка чүп үлән орлыклары калдырыла.* Соц. Тат.

СОЛЬ *и. махс.* **1.** „До“ белән башланган музыкаль авазлар системасында бишенче тон.

2. Музыка әлифбасында шушы авазны белдергән нота.

СОЛЯ'РИЙ *и. махс.* Кояш ваннасы өчен булган мәйданчык. *Дә солдарак ак комлык, күрәсезме? Анда безнең солярий. Хәзер инде авыл кешеләре дә кояшта кызынырга өйрәнә башладылар. Элегрәк аларны анда тартып та илтеп булмый иде.* Г. Әпсәләмов.

СОЛЯ'РКА *и. тех.* Дизель ягулыгына, майлауга һ. б. ш. китә торган, нефтьтән алынган матдә. *Бер җирдә биш-алты шофер җыелып солярка яндыралар. Ут янында җылыналар.* М. Хәсәнов.

СОНА'ТА *и. махс.* Бер яки ике уен коралы өчен язылган, төрле төрдәге өч-дүрт кисәкле музыкаль әсәр.

СОНАТИ'НА *и. махс.* Кечкенә соната.

СОНГЫЙ *с. иск. кит.* Табигый түгел, чын түгел; ясалма. *Тәүфикъ тавышына сонгый җитдилек бирепсөйләп китте.* Ш. Усманов. *Ул ролендә бөтенләй Карцевлектән чыгып, сонгый героеның нәкъ үзе булып әверелә.* Ш. Әхмәдиев.

СОНЕ'Т *и. әд.* Ике дүртьюллык белән ике өчьюллыктан төзелгән ундүрт юллы лирик шигырь.

СОНО'Р: сонор тартыклар *лингв.*— *р, л, м, н* тартыклары (аларны әйткәндә тавыш өстенлек алып, шаулау кимрәк ишетелә).

СОНУ *ф. иск.* Бирергә дип сузу, тәкъдим итү. *Дәүләтша агай сәдака сонды, хәзрәт алып дога кылды.* З. Һади. *Ул кулындагы чәчәк бәйләмен Хәяткә сонды.* Ф. Әмирхан.

СО'ПЛО, СОПЛО' *и. махс.* Газ, пар яки сыеклык агынтысына юнәлеш һәм тизләнеш бирү өчен җайланган көпшә, канал.

СОПРА'НО *и. махс.* **1.** Иң югары (нечкә) хатын-кыз тавышы. *Сопрано белән җырлау.*

2. Шундый тавышлы җырчы хатын-кыз.

СОП-СОРЫ *с. Артык. дәр. к.* соры.

СОРАМЫЙ, СОРАМЫЙЧА *рәв.* Рөхсәтсез. [*Әнисе — улына:*] *Алай сорамыйча алырга ярамый, акыллым, бар, урынына илтеп куй* [*кеше әйберен*]. Г. Гобәй.

СОРАНУ *ф.* Теләнчелек итү, теләнү, хәер сорап йөрү. *Бер көнне боларга карт бер теләнче: „Алла хакы өчен бер генә телем икмәк“,— дип соранып кергән.* Ә. Фәйзи. *Әтисе сугышта югалган икән, әнкәсе, соранып йөргән чакта, ике авыл арасында буранда катып үлгән.* И. Гази.

СОРАТУ *ф. Йөкл. юн. к.* сорау I (1, 2, 4 мәгъ.). || Кеше аркылы сорау-үтенү. *Ни өчен ат соратмадыгыз, җибәргән булыр идек, ди Хәбибуллин, хәбәрченең хәтерен күрер өчен генә.* Ә. Еники. *Борынгылар әйткәннәр, кем икәнеңне беләсең килсә — кыз сорат, дигәннәр.* А. Шамов.

СОРАУ I *ф.* **1.** Берәр нәрсәне белергә-белешергә теләп мөрәҗәгать итү. *Берәүнең исемен-фамилиясен сорау. Хатта кардәшләреңнең саулыгы-тазалыгы турында сорау. Кешенең адресын, телефон номерын сорау.* □ *Сагынасыңмы дип сорыйлар, Сагынмаган кая ул.* Җыр. *Галим белсә дә сорый, надан белми дә, сорамый да.* Н. Исәнбәт. || Дәрестә: элек өйрәнгәнне кабатлап аңлатып бирергә яки өйдә укыганны сөйләп-аңлатып бирергә кушу. *Укучыны такта янына чыгарып сорау. Авыр үзләштерүче укучылардан ешрак сорау.* □ *Әдәбият сәгатьләрендә Шанмәс, үзеннән дәрес сорамасалар, күтәрелеп тә карамый торган булды.* Б. Камалов.

2. Берәр нәрсә бирүне яки эшләүне үтенү, шундый үтенеч белән мөрәҗәгать итү. *Ярдәм сорау. Бурычка акча сорау. Киңәш сорау.* □ *Кызым Нәилә һәрвакыт Уенчык сорый миннән.* Г. Латыйп. *Ана баласының шулай әйбәт итеп рөхсәт соравына бик шатланды.* А. Әхмәт. || Хатын-кызның кияүгә чыгарга ризалыгын үтенеп мөрәҗәгать итү.— *Таҗига Шакәримнең Гөлйөземен сорап йөриләр ди.* М. Фәйзи. || Катгый үтенү, таләп итү, кушу.— *Сырхау кешедән эш сорамыйлар, аны дәвалыйлар.* Ш. Камал. || Берәр эш-хәл өчен җавап-хисап бирүне таләп итү, җавапка тарту. [*Директор:*] *Заводта авария булган икән, партия аның өчен иң башлап миннән сорый.* Р. Ишморат.

3. Берәү турында белергә яки аны күрергә теләүне әйтеп мөрәҗәгать итү, аны (гадәттә кеше аркылы) чакыру. [*Әпипә:*] *Ничә кеше килеп сорады инде шул Нәфисәне. Д менә мине берсе дә сорамый. Гел ул да гел ул.* Г. Бәширов. [*Иптәш артисты — Зөһрәгә:*] *Һаман алкыш! Сезне сорыйлар. Чыгасыз, туташ.* Н. Исәнбәт.

4. Билгеләү-кую, таләп итү (хакны, бәяне һ. б. ш.). [*Итекчеләр*] *инде итекне өч тәңкәгә генә бирмиләр,*

кыйбатрак сорый башладылар. Г. Тукай. *Сатулашучылар бертуктамый кул сугышалар: чуваш сиксән биш тиен сорый, татар сиксән өч тиен бирә.* Ф. Әмирхан.

5. Хезмәт-көч куярга, игътибар-әһәмият бирергә, сәләтне-тәҗрибәне һәм мөмкинлекләрне файдаланырга, чыгымнар ясарга һ. б. ш. мәҗбүр итү, шуны эшләргә зарур хәлгә кую (эш-хезмәт һ. б. турында). *Күп урын сорый торган мәкалә. Зур осталык һәм саклык сорый торган эш. Күп чыгым сорый торган сәяхәт.* □ *Бик зур тәвәккәллек тә, бик нык түземлек тә сорый торган кызык эш бит бу.* Г. Бәширов. *Күп корбаннар сораган авыр, данлыклы көрәш безне хәзер якындагы коммунизмның балкышы киңлекләренә китереп чыгарды.* М. Максуд. *Көрәш йокысыз төннәрне, газаплы көннәрне, чыдамлыкны сорый.* Н. Дәүли.

СОРАУ II *и.* **1.** Җавап яки аңлатма бирү таләп ителә торган мөрәҗәгать, сүз. *Докладчыга сораулар бирү.* □ *Егет җавап бирмәде, әллә соравымны ишетмәде, әллә ишетеп тә, кем булуын һәм кайдалыгын әйтергә теләмәде.* А. Шамов.— *Сезгә бер соравым бар.* Ә. Айдар. || Үтенеч. [*Зифа:*] *Сүземне тыңламасаң, үпкәлим.* [*Чингизов:*] *Ярый, мин синең соравыңны үтим.* Т. Гыйззәт. *Ул безнең сорауны тыңлар дип уйлыйм.* Ш. Камал.

2. Аңлашылмаган нәрсә, ачыклыйсы мәсьәлә, проблема турында. *Мине бер сорау борчый.* Р. Ишморат. *Бу улмы? — Менә шул хатирәләр түреннән чыгып Искәндәров алдына баскан, аның йөрәген туктаусыз борчып торган сорау шушы иде.* Ә. Еники.

3. *махс.* Җинаять һ. б. нәрсәне ачу, тикшерү эше: сөйләтү, мәгълүматлар әйттерү; *русчасы:* допрос. *Камерада тагын күмер кебек кап-кара бер кеше бар. Аны көн саен диярлек сорауга чакыралар иде.* Г. Әпсәләмов. *Сорау да һаман татарча барды. Җитмәсә тагын, моның сөйләгәннәрен --- яшь егет татарча яза торды. Әби бераз тынычланды.* Г. Ибраһимов.

4. *махс.* Кулланучының ижтимагый таләбе, берәр товарны, эш көчен кирәксенүе, аңа ихтыяҗы. *Сатып алучыларның сорауларын өйрәнү өчен кибетләргә белгечләр җибәрелә.* Азат Хатын. *Культура сораулары һаман үсә бара.* М. Максуд. *Узган елдагы темплар быелгы сорауларны канәгатьләндермәячәк.* Ф. Хөсни.

5. *с. мәгъ.* Сорауны белдерә торган. *Сорау җөмлә.*

◇ **Сорау алу** — җинаятьне һ. б. ш. ачканда, тикшергәндә: сөйләтү, мәгълүматлар әйттерү. *Үз-үзеңнән сорау алам: Кемгә каршы тордың син, Гата?* Ш. Маннур.

СОРАУЛЫ *с.* Сорауны, белергә теләүне күрсәтә торган (мөрәҗәгать, караш һ. б. ш. турында). *Әнә, әнисе аңа сораулы карашын төбәгән дә, бу эшнең ничек булуын аңлатып бирүне көтә шикелле.* Г. Минский. *Һәммәсе дә хәрәкәтләреннән туктап, сораулы күзләре белән безгә текәлеп калдылар.* М. Әмир. || Сорауны эченә алган (интонация һ. б. ш. турында).

СОРАУЛЫК *и.* Берәр мәсьәлә, тема буенча мәгълүмат жыю-туплау өчен төзелгән сораулар исемлеге. *Сораулык төзү, эшләү. Диалектологик сораулык.*

СОРАУСЫЗ *с.* **1.** Сорауны эченә алмаган, турыдантуры сорау сүзе яки җөмләсе булмаган (дәреслектәге мәсьәләләр, сөйләмдәге җөмләләр һ. б. ш. турында).

2. *рәв. мәгъ.* Сорамыйча, рөхсәтсез (берәр нәрсә эшләү, әйбер алу-бирү һ. б. ш. турында). *Ата-анадан сораусыз кинога бармаучы үсмер. Берәүнең альбомын сораусыз карау. Балаларның китап киштәсендә сораусыз актарынмавы.* □ *Гайрәтле бай хатыны, кәефләнеп, бөтен дөньяга баш кебек булып йөргән вакытта, ничек инде андый хәерчеләрнең монда сораусыз-нисез керүенә ачуланмасын?!* М. Гафури.

СОРАШТЫРУ *ф.* **1.** *Каб. дәр. к.* сорау I (1—3 мәгъ.).

2. Кабат-кабат сорау биреп, сорашу. *Читтән кайтучыдан андагы тормышны, эш-хәлләрне сораштыру.* □ *Газинур ипташларыннан кайда эшләүләре турында сораштыра башлады.* Г. Әпсәләмов.

СОРАШУ *ф.* **1.** *Урт. юн. к.* сорау I (1—3 мәгъ.). *Исәнлек-саулык сорашу. Хәл-әхвәл сорашу.*

2. Кабат-кабат сорап, бер-бер артлы сораулар биреп, берәр нәрсә турында белергә тырышу, белешергә теләү. *Эшнең ничек алай килеп чыгуы турында нечкәләп сорашып торырга өлгерә алмый калдык.* М. Әмир. *Якуп Шәрифҗан турында сорашты: кайда йөри ул?* И. Гази. *Самовар куйган арада Газизә апа Габдулладан бик күп нәрсәләр сорашты.* Ә. Фәйзи.

3. Хәер сорап, теләнеп йөрү; теләнчелек итү; сорану.— *Мин хәер сорашмыйм, мин хәерче түгел.* Ш. Мөхәммәдев.

СОРГЫЛТ *с. Ким. дәр. к.* соры. *Садыйк хажи, озын һәм чүбек төсле соргылт ак кашлары астыннан түбән караган килеш бераз уйлап торганнан соң, кинәт сорау бирде.* Ш. Камал. *Без юлга чыкканда караңгы иде әле. Көзнең соңга калган таңын, беренче соргылт яктылыкны юлда каршыладык.* Г. Иделле.

СОРГЫЛТЛАНУ *ф.* Соргылт төскә керү, соргылтка әйләнү.

СОРНАЙ *и.* Өреп уйнала торган борынгы уен коралы. *Берәү сорнай өрде, икенчесе әкрен генә думбра уйнады.* Х. Мөҗәй. *Җиденче ротадагы румыннар, сыер куыгыннан ясаган сорнайларын кычкыртып, сөяк [шапылдавыклар] шакылдатып, гаҗәп төзек тавышлы оркестр оештырдылар.* Ш. Усманов.

СОРНАЙЧЫ *и.* Сорнай уйнаучы, шул һөнәрнең остасы. *Аны авызларына бик озын быргылар капкан сорнайчылар, барабан кагучы, сөңгеле сакчылар урап алган.* Н. Исәнбәт.

СОРТ *и.* Төрдәшләреннән үзенең сыйфаты, кыйммәте белән аерыла торган төр. *Агачны сортларга аеру.* □ *Яңа сорт бодай чәчәбез.* Р. Ишморат.— *Син алмагачның тышкы кыяфәтенә кызыкма, әсортына игътибар ит. Суыкка чыдый торган сорт булсын, тизрәк алма бирә торган сорт булсын.* И. Гази.

СОРТА'МЕНТ *и.* Гадәттә металлургиядә: бер иштән булган эшләнмәләрнең төрле сортлары, төрләре җыелмасы. *Табаклы калай сортаменты.*

СОРТИМЕНТ *и.* Гадәттә урманчылык эшендә: бер иштән булган эшләнмәләрнең төрле сортлары, төрләре җыелмасы. *Агач материаллары сортименты.*

СОРТИРО'ВКА *и.* Ашлыкны сортларга аеру, чүп үлән орлыкларыннан арындыру һ. б. ш. өчен хезмәт итә торган авыл хуҗалыгы машинасы. *Сортировкада эшләү.*

СОРТИРОВКАЛАУ *ф.* Сортировка аркылы уздырып эшкәртү: сортлау, чистарту һ. б. ш. *Ваня белән Андриян орлыклык борчак чистартуны шул тикле тиз тоттылар, --- хәтта бригадир үзе дә бригадада борчак сортировкалау тәмамлануны белмичә калды.* К. Латыйпов.

СОРТЛАУ *ф.* Сортларга аеру. *Орлык сортлау.* □ [*Хәдичә Мәдинәгә:*] *Хәзергә тышта, әзер такталарны сортлап штабельләргә өеп торачаксың.* М. Хәсәнов. *Үзем өйрәтермен, дигән Майпәрвәз, кырт кисеп. Һәм Идиятен агент иткән, күкәйне танырга, тирене сортлый белергә өйрәткән.* Ә. Еники.

СОРТЛЫ *с.* Югары сортлы, яхшы. *Аларга тәмле җимеш бирә торган яңа сорт агачларның ботакларын ялгыйлар. Шулай итеп, урманнарда күп гомерләр кыргый хәлдә калган бу агачлар, безнең бакчага күчереп утырткач, сортлы җимеш агачларына*

әвереләләр. Г. Галиев. [*Фәрдәнә:*] *Тәҗрибә кырына сортлы орлыклар алырга барам.* Т. Гыйззәт.

СОРТСЫЗ *с.* Түбән сыйфатлы, начар сортлы. *Узган ел „Волга" колхозында бәрәңгенең һәр гектарыннан ике йөз центнердан артык уңыш алсалар, „Яңа тормыш"та аның яртысы гына булды. Очраклы күренеш түгел бу. Чөнки колхозда әлегә кадәр сортсыз бәрәңге игеп килделәр.* Соц. Тат.

СОРХАНТАЙ *и. шелт.* Эшсез вакыт уздыручы, ялкау. *Теге эшсез сорхантайлар, ачу китереп, тел шомартып торган булалар.* Ф. Хөсни.

СОРЫ *с.* Сарыдан караңгырак (төс турында). *Балавыз төсле соры, озынча гәүдәле, кыска канатлы --- ана корт кәрәз күзәнәге саен йомырка салып йөри.* А. Алиш. [*Малайның*] *башындагы актан сорыга әйләнгән зур киез эшләпә, мөгаен, әтисеннән калган.* М. Әмир.

СОРЫКОРТ, СОРЫ КОРТ 1. Умартада: эш эшләмәүче, әзерне ашап кына ятучы ата корт.

2. *күч.* Бүтәннәр хезмәтеннән файдаланып, кеше исәбенә яшәүче. *Кулак белән карчык күздән югалгач, каравыл өе, гөр килеп, бу соры кортны каргап калды.* Г. Бакиров. *Соры кортның, талаучының Барын себереп түгәрмен.* М. Максуд.

СОРЫЛАНУ *ф.* Соры төскә керү, сорыга әйләнү. *Бу — Зөбәрҗәт күзләре бит. Ә нигә соң алар сорыландылар, саргайдылар?* Г. Ахунов.

СОС *с.* 1. Төбәгән җиргә бик туры тидерүче.

2. Сәләтле, зирәк (эшкә һ. б. ш.). *Башта Миләүшәне ярдәмче итеп кенә куйганнар иде дә, икеме-өчме көннән соң, андагы апаның берсен --- җибәрделәр. Мин, башлык буларак, мыекка бөтереп куйдым бу фактны: күрәсең, мәйтәм, минем кычытkан чыпчыгым андагы эшкә сос булып чыкты.* Ф. Хөсни.

СОСА *и.* Туку, киндер сугу станында: аркау җебе уралган шүрене йөртә торган җайланма. *Сөйләшәләр, гөрләшәләр Корыч көрелә; Мең-мең соса уңга, сулга Очып йөриләр.* М. Сөндекле. || Тегү машинасында: теккәндә җепле шүрене йөртә торган җайланма. *Машина сосасы. Түгәрәк соса.*

СОСИ'СКА *и.* Вак-вак нечкә кисәкле итеп эшләнгән, пешереп ашала торган колбаса. *Монда колбасаны гел кайтарып торалар икән. Кайчакны сосискага кадәр була ди.* Г. Мөхәммәтшин.

СОСКЫ *и.* Бөртекле, вак-вак кисәкле һ. б. ш. нәрсәләрне алу-салу өчен кулланыла торган, гадәттә колашаландырып (яссы булганда, читле итеп) ясаган, көрәкчек сыман корал. *Күмер соскысы.* □ [*Сатучы хатынның*] *соскы тоткан ак, нәфис куллары да нур бөркеп тора.* Н. Фәттах. *Аның эченә таралып китте. Ул тарттырылган онны, соскы белән үз капчыгына салам дип, янәшә торган кеше капчыгына сала язды.* Ә. Фәйзи.

СОСКЫЧ *и.* Чумырып (сосып) ала торган, зур чүмеч сыман корал. *Тозланган селедканы озын саплы соскычлар белән чаннардан сөзеп чыгара баралар; хатыннар, ише-ише белән сайлап, мичкәләргә тутыра иделәр.* Ш. Камал. *Соскыч белән су сибеп тордым. Берничә тапкыр шулай кабатлау нәтиҗәсендә әлеге ярык кына түгел, бөтен көймә төбе боз белән капланды.* С. Сабиров. *Әнкәй казаннан чуен чүлмәккә тавыклар бәрәңгесе — кабыклы вак бәрәңге сосып маташа иде. --- Алюмин чыбыктан үрелгән соскычын казан читенә элде.* Каз. утл. || *диал. к.* соскы. *Карлыгач белән Сөмбел бер башын әлгән зур тимер кисмәккә чиләкләр һәм соскычлар белән ашыга-ашыга бодай тутыралар.* Г. Бәширов.

СОСЛАНУ *ф.* Төбәгән җиргә тидерүдә бик остару, соска әйләнү.

СОСЛО'ВИЕ *и. тар.* Капитализмга кадәрге чор дәүләтләре өчен хас, хокуклары-бурычлары юридик актлар белән беркетелеп нәсел буенча күчә килгән бер иҗтимагый төркем, сыйнфый катлам. *Борынгы Рим сословиеләре. Сословиеләргә бүленү. Рухани сословие. Купец сословиесе. Дворян сословиесе. Мещан сословиесе. Югары сословиеләр.* □ *Крестьян халкы башка сословиеләр белмәгән түләүләрне үзе генә түләп килде.* Урал.

СОСЛОВИЕЛЕ *с. тар.* 1. Сословиеләргә бүленгән, сословиеләрдән торган (җәмгыять турында); сословиеләре булган (дәүләт турында). *Сословиеле җәмгыять. Сословиеле дәүләт.*

2. *к.* сословиечел (1 мәгъ.). *Сословиеле оешма.*

СОСЛОВИЕЧЕЛ *с. тар.* 1. Сословиеләргә бүленгән җәмгыять өчен хас. *Сословиечел дәүләт. Сословиечел сайлау системасы. Сословиечел уку йортлары.*

2. Югары, привилегияле сословиеләргә таянып, шуларның вәкилләре ,катнашында башкарыла торган (дәүләт идарәсе һ. б. турында). *Сословиечел идарә. Сословиечел монархия.*

3. Югары, привилегияле сословиеләргә хас, бүтән сословиеләргә түбәнсетеп карауга нигезләнгән. *Сословиечел хорафатлар. Сословиечел рух.*

СОСЛОВИЕЧЕЛЕК *и.* Сословиеләргә бүленгәнлек хәле. *Сословиечелеккә каршы протест белдерү.*

СОСЛЫК *и.* Сос кешегә хас сыйфат. *Малайлар минем бу сослыкны [ыргыткан җиргә бик туры тидерүемне] хуплап үзара шаркылдашырга тотындылар.* Ф. Хөсни.

СОСТАВ *и.* 1. *гадәттә тартымлы форм.* Берәр җирдә эшләүче, оешманы тәшкил итүче һ. б. ш. кешеләр төркеме. *Бюроның яңа төзелгән составы. Колхозның идарә составына сайлану. Комиссиянең составын тулыландыру. Президиум составы. Полкның тулы состав белән маневрга катнашуы.* □ *Нәфисә фронтка бүләк алып баручы делегация составына кертелде.* Г. Бәширов. *Шул ук елны көзен партиянең район конференциясендә ул [Мостафин] райком составыннан төшеп калды.* Ә. Еники.

2. *гадәттә тартымлы форм.* Берәр нәрсәнең эчке төзелешен, аның эчтәлеген, структурасын тәшкил иткән берәмлекләр. *Дарунның составын үзгәртү. Телнең фонемалар составын барлау. Сүзлек составы бай. Нефть составындагы майлар. Матдәнең химик составы. Җәмгыятьнең сыйнфый составы. Җөмлә составын тикшерү.* □ *Әдипнең сүз составы авылдан алынган.* Г. Нигъмәти.

3. *махс.* Бер поезд итеп тагылган вагоннар һ. б. ш. транспорт комплекты. *Поезд составын үзәк станциядә туплау. Йөкле состав. Тайгадан урман чыгара торган махсус чаналарны состав итеп тезеп трактор тагу.* □ *Алдагы эшелоннарда Оренбург эшче полкы урнашкан. Өч мең ярым кешелек бу полк җиде-сигез состав алган.* Ш. Усманов. *Ул озын бер составка тезелгән тимер юл вагоннарын күрде.* Каз. утл.

4. *махс.* Берничә химик элементны яки матдәне кушып ясаган матдә. *Яңа состав ясау.* □ [*Мастер:*] *Моннан ике генә көн элек бездә моны [киемдәге тапны] бетерә торган состав бар иде.* Г. Галиев.

СОСУ *ф.* 1. Чүмеч һ. б. ш. нәрсә белән чумырып алу. *Үзлегеннән күтәрелде табындагы бер кашык!.. Шулпаны сосып ала да үзе менә һавага...* Н. Исәнбәт. [*Экскаваторчы*] *балчыкны сосып ала да бункерга бушата.* Соц. Тат. || *диал.* Аш һ. б. ш. нәрсәне: бүлү, савытка бушату. *Ул табактан Шаяхмәт тәлинкәсенә пилмән сосып тора иде.* Г. Ибраһимов. *Әбием иң беренче бабай тәлинкәсен алып аш соса.* Н. Дәүли.

2. *күч. сөйл.* Кабалана-кабалана, әдәпсезләнеп-комсызланып һәм күп итеп ашау. *Алга килгән берсен сосып бару.*

3. *күч. сөйл.* Законсыз-намуссыз рәвештә җыя-үзләштерә бару. *Безнең шәһәр байлары Мәскәү малын сосалар, Корзинкалап сыра эчкәч, чыдый алмый косалар.* Ш. Мөхәммәдев. [*Фатыйма — үз авыл кулагына алманың бөтен уңышын тулаем сатарга җыенган иренә:*] *Читтән килгән алма байлары кыйбатрак бирүчән булалар, сатма шул комсыз шайтанга, болай да авылның бөтен байлыгын сосып тора инде ул.* И. Гази.

4. *күч. сөйл.* Сугу, кыйнау. [*Бер малай икенчесенә:*] *Тиеп кенә кара, менә монау таяк белән сосам.* Г. Гобәй. *Сүс чыбыркысы белән юри генә, искәртер өчен генә берәрне сосып та алгач, аның үшән биясе әкрен генә атлап су аркылы чыгып китә.* Ш. Маннур.

СО'ТНИК *и. тар.* **1.** Патша армиясе составындагы казачий гаскәрдә: кавалерия ротмистры белән тиң хәрби дәрәҗә. || Шушы дәрәҗәне алган офицер.

2. Унҗиденче гасырларга кадәрге рус һәм украин гаскәрләрендә: йөз кешелек берләшмә (сотня) командиры. *Стрелец сотнигы. Богдан Хмельницкий гаскәрендәге сотник.*

3. *сөйл. к.* сотский. *Шул турыда бүген староста, сотниклар киңәшкәннәр дә җиде җиргә каравыл куярга булганнар.* Т. Гыйззәт.

СО'ТСКИЙ *и. тар.* Патша Россиясендә: авыл җире полициясенә ярдәмгә билгеләнгән крестьян (1861 елгы реформадан соң авыл старостасына, волость старшинасына һәм полиция уряднигына буйсынган). *Десятский һәм сотскийлар, күкрәкләренә калай „медальләрен" тагып, кулларына таяклар тотып, өй борынча йөреп --- халыкны таяклап җыенга куа башладылар.* М. Гафури.

СО'ТЫЙ *и. сөйл.* **1.** Гектарның йөздән бер өлешенә тигез булган җир үлчәү берәмлеге; ар. *Бакча шактый зур гына икән, кимендә бер сигез сотый җир билән тора булса кирәк.* Ә. Еники.— *Утыз биш сотый гына [сөрәсе] калды, малайлар!* Г. Гобәй.

2. Колхозда: хезмәт көненең йөздән бер өлеше. *Без аңа укыган вакытында [көнгә] 75 сотый хезмәт көне бирдек.* Ә. Айдар.

СО'УС *и.* Әзер ашамлыкка кушып бирелә торган (сыек) аш тәмләткеч.

СО'УСЛЫ *с.* Соусы булган, соус салынган, катнаштырылган (ашамлыклар турында).

СОФИЗМ *и. кит.* Формаль яктан дөрес, ләкин асылда ялгыш фикер, ялган фикри нәтиҗә; ялгыштыруга-бутауга исәп тотып төзелгән сөйләм. || *күч.* Фикерне бутап, дөреслекне яшерү максаты белән эшләнгән логик хәйлә, сүз уйнату.

СОФИСТ *и. кит.* Софистик алым белән фикер йөртүче, фикерен софизм ярдәмендә дәлилләүче. || *күч.* Фикерне бутап, дөреслектән читкә алып китү максаты белән сүз уйнатучы.

СОФИ'СТИК *с. кит.* Софизмга нигезләнгән, шуны файдалана торган. *Софистик алым. Софистик фикер. Софистик уйдырма.* □ *Муса Җәлил халкыбыз сөйли торган телдә яза иде. Тел сафлыгы турында софистик бәхәсләшүләргә бирелми иде.* М. Максуд.

СОХАРИ *и.* Телемләп киптергән ипи. *Сохари киптерү.* □ *Артельщик солдат, аркасына капчык белән сохари күтәреп кереп:— Бүген икмәк китермәгәннәр, солдат башына яртышар кадак сохари бирделәр. Шуны иртә белән кадәр җиткерәсез,— дип, кеше башына икешәр-өчәр кисәк күгәреп, каешланып беткән кара икмәк сохарие өләшеп чыкты.* М. Гали.

СОЦ- Кушма сүзләрдә „социалистик", „социаль" мәгънәсендәге беренче кисәк.

СОЦИАЛ- Парлы сүзләрнең „социал-демократиягә мөнәсәбәтле" дигән мәгънә белдерә торган беренче кисәге, мәсәлән: **социал-империализм, социал-патриот, социал-пацифист, социал-шовинизм.**

СОЦИАЛ-ДЕМОКРАТ *и.* **1.** Социал-демократия (1 мәгъ.) тарафдары, вак буржуаз оппортунист.

2. Социал-демократик партия члены. *Икенче Дума куылды. Андагы социал-демократлар фракциясеннән илле кеше ябылды.* Г. Ибраһимов. *Нурый Сәгыйтов социал-демократ булган икән, шуның өчен бернәрсәдән дә курыкмый көрәшеп, шундый авыр җәзага дучар булган икән.* М. Гафури.

СОЦИАЛ-ДЕМОКРАТИЗМ *и.* Социал-демократиянең идеологиясе һәм тактикасы.

СОЦИАЛ-ДЕМОКРА'ТИК *с.* Социал-демократиягә мөнәсәбәтле. *Социал-демократик партия. Социал-демократик карашлар.*

СОЦИАЛ-ДЕМОКРА'ТИЯ *и.* **1.** Халыкара эшчеләр хәрәкәтендә: социалистик асылын югалтып, вак буржуаз оппортунистик агымга әверелгән политик юнәлеш.

2. XIX йөзнең соңгы чирегендә барлыкка килгән социалистик партияләрнең гомуми исеме. *Россия социал-демократиясе.* □ *Урыннарда, губерна жандармерия кәгазьләрендә генә түгел, Петербургта департамент докладларында да панисламизм, пантюркизм белән татар социал-демократиясен бергә бутап, бер аршын белән үлчәп, йөдәп чыгалар.* Г. Ибраһимов.

СОЦИАЛИЗАЦИЯЛӘҮ *ф.* Милекне һ. б. нәрсәне: социалистик итү, бөтен җәмгыятьнекенә әйләндерү.

СОЦИАЛИЗМ *и.* **1.** Пролетар революция җинеп һәм буржуазия хакимлеге бетерелеп, пролетариат диктатурасы урнашу нәтиҗәсендә барлыкка килгән җәмгыять һәм дәүләт строе; коммунизмның беренче (түбәнге) фазасы (социализмның җитештерү мөнәсәбәтләре нигезен җитештерү чараларына иҗтимагый милек тәшкил итә; социализмда „һәркемнән сәләтенчә, һәркемгә хезмәтенчә" принцибы тормышка ашырыла). *Социализм лагере.* □ *Социализм төзибез Күмәк хуҗалык белән.* Җыр. *Радио эфир аша Җир шарына социализм иленең җиңүен хәбәр итә!* Һ. Такташ.

2. Социалистик җәмгыять төзү турындагы тәгълимат. *Социализмны өйрәнү.* □ *Мәҗит Гафуриның демократик идеяләр аркылы социализмга килгән катлаулы иҗат юлы әдәбият тарихыбызны өйрәнүдә зур әһәмияткә ия.* М. Җәлил.

3. Төрле буржуаз һәм вак буржуаз тәгълиматлар (антагонистик каршылыкларны йомшартып яки тигезләүчелек кертеп капиталистик җәмгыятькә реформа ясау турында). *Христиан социализмы. Мещан социализмы.*

СОЦИАЛИСТ *и.* **1.** Социализм тарафдары. *Маркс-Энгельсның турыдан-туры җитәкчелеге астында эшләгән I Интернационал дәверендә --- төрле агым социалистларының бер оешма эчендә эшләүләре безгә гыйбрәт булырга тиеш.* Г. Ибраһимов. *Ул төрле партияләрдән һәм партиясез социалистлардан оештырылган Мөселман социалистлар комитетларының тарихи бурычлары Мөселман милли комитетларына каршы көрәштә чикләнә дип уйлый иде.* К. Тинчурин.

2. Социалистик партия члены. *Сәгыйтов социалист булган икән. Ул шул партиядә булып, эшчеләр тарафыннан басылган нәрсәләрне солдатлар арасына таратып йөргән, имеш.* М. Гафури.

СОЦИАЛИ'СТИК *с.* 1. Социализм строена хас. *Социалистик җитештерү ысулы. Социалистик җитештерү мөнәсәбәтләре. Социалистик милек.* || Җәмгыятьне социализм принциплары нигезендә үзгәртеп кору максатына буйсынган. *Социалистик революция. Социалистик үзгәртеп корулар. Социалистик хәрәкәт.*

2. Социализм принципларына нигезләнгән. *Социалистик җәмгыять. Социалистик ил. Социалистик система.* || Социализм принципларына нигезләнгән җәмгыятькә хас. *Социалистик хуҗалык. Социалистик культура. Социалистик үсеш юлы.* □ *Кил, чәчәк күрсәт җиһанга, социалистик милләтем.* Н. Исәнбәт.

3. Социализм идеяләре белән сугарылган, аның принципларына туры килә торган. *Социалистик аң. Социалистик тәрбия. Социалистик хезмәт. Социалистик идеология. Социалистик реализм методы.* □ *— Сез социалистик ярыш байрагын беренче булып күтәрдегез, өстегезгә бик зур йөкләмәләр алдыгыз.* Г. Бәширов.

4. Социал-демократиягә мөнәсәбәтле. *Социалистик партия.*

СОЦИАЛ-ШОВИНИЗМ *и.* Халыкара эшчеләр хәрәкәтендәге (беренче бөтендөнья сугышы чорында II Интернационал партияләре һәм җитәкчеләре арасындагы) оппортунистик агым.

СОЦИАЛ-ШОВИНИСТ *и.* Социал-шовинизм тарафдары.

СОЦИАЛЬ *с.* 1. Җәмгыятькә мөнәсәбәтле, бәйле; иҗтимагый. *Социаль проблема. Социаль үзгәрешләр. Социаль тигезсезлекне бетерү өчен көрәш. Социаль тормыш.* □ *Сезнең чорда, шиксез, социаль чыгыш зур бер нәрсә итеп каралмас.* Һ. Такташ. *Кешенең матурлыгы һәм аның социаль йөзе иҗтимагый хезмәтеннән аерым карала алмый.* Г. Кашшаф.

2. Иҗтимагый җитештерү мөнәсәбәтләрен фәнни үзгәртүне максат итеп куя торган. *Социаль революция.*

3. Җәмгыять тарафыннан башкарыла, эшләнә торган, аның вазифасына караган. *Социаль тәэминат.*

СОЦИО'ЛОГ *и.* 1. Социология белгече.

2. Социологизм тарафдары.

СОЦИОЛОГИЗМ *и.* 1. Иҗтимагый күренешләрне социология тәгълиматы нигезендә аңлау-аңлату.

2. Чынбарлыкның төрле формалары үзенчәлеген исәпкә алмыйча, күренешләрнең иҗтимагый-тарихи шартлылыгын-сәбәплелеген артык гадиләштереп аңлау-аңлату.

СОЦИОЛО'ГИК *с.* Социологиягә мөнәсәбәтле, шуны чагылдыра торган. *Социологик төшенчә, закончалык. Социологик фаразлар. Социологик тикшеренү.* □ *Татар мәгърифәтчеләренең социологик карашларына тарихи оптимизм хас.* Каз. утл. || Социология өлкәсендәге тикшеренүләргә мөнәсәбәтле. *Социологик план.*

СОЦИОЛО'ГИЯ *и.* Иҗтимагый системаларның, шул исәптән тулаем җәмгыятьнең үсеш һәм яшәү закончалыклары турындагы фән (эмпирик методлардан файдаланып, төрле социаль күренешләрнең үзара бәйләнешен һәм кешеләрнең иҗтимагый үз-үзен тотышындагы гомуми закончалыкларны тикшерә).

СОЧИНЕ'НИЕ *и. махс.* Укучының тел-әдәбият буенча берәр темага үз сүзләре белән язган мөстәкыйль эше. *Институтка кергәндә язылa торган сочинение темалары. Ана теленнән сочинение дәресе. Сочинение дәфтәре.*

СОЮЗ *и.* 1. Сыйныфлар, иҗтимагый төркемнәр берләшүе, аларның шул нигездәге бәйләнеше. *Эшче һәм крестьяннар союзы.* || Дәүләтләр, оешмалар һ. б. берләшмәсе. *Хәрби союз. Дипломатик союз.*

2. Дәүләтчел берләшмә. *Австралия союзы. Кабиләләр союзы. Совет Социалистик Республикалар Союзы.*

3. Җәмәгать оешмасы. *СССР архитекторлар союзы.* □ *Язучылар союзы һәм композиторлар союзы бердәм иҗат эшен көчәйтергә тиешләр.* М. Җәлил. *Ахырда типография эшчеләрг союзыннан ике вәкил килеп, хуҗа белән эшчеләрне килештерделәр.* Ш. Камал.

СОЮЗАРА *с.* Берничә союз өчен уртак булган. *Союзара элемтә.*

СОЮЗДАШ *с.* Бер үк союзга (1, 2 мәгъ.) берләшкән, бер үк союзда торучы. *Союздаш республикалар. Союздаш дәүләт. Союздаш ил. Союздаш армия. Союздаш дуслар.* □ *Совет Россиясе һәм аның союздашларының хәрби потенциалы Германиянең һәм аның союздашлары Япония белән Италиянең хәрби потенциалларыннан артыграк иде.* Каз. утл.

СОЮЗДАШЛЫК *и.* Бер үк союзда тору хәле. *Такташ Октябрь елларында революциягә юлаучылыктан пролетариат әдәбиятына союздашлыкка таба үсте.* Г. Нигъмәти.

СО'Я *и.* Кузаклылар семьялыгына керә торган үлән үсемлек (бөртеге азыкка һәм техник ихтыяҗга китә). *Үсемлек майларын көнбагыш, җитен, киндер, соя һ. б. орлыклардан сыгып чыгаралар.* А. Расих.

СОҢ I *рәв.* 1. Гадәттәгедән кичегеп, тиешле вакытыннан артка калып (эшләү, хәрәкәт итү һ. б. ш. турында). *Эштән бик соң кайту. Яз соң килү. Соң өлгерә торган ашлык.* □ *Бер бала иртән йокысыннан бик соң тора икән. Атасы моны, үгетләп, бу гадәтеннән биздермәкче булган.* Г. Бәширов. *Соң чыкссак та җитәрбез без.* Г. Ибраһимов. || Вакытны белдергән сүздән соң: „күрсәтелгән вакыт узгач“, „шуның кадәр кичегеп, соңрак“ дигәнне белдерә. *Галиәсгар Камалдан биш-алты ел соң әдәбият мәйданына чыккан Тукай да әле үзенең беренче әсәрләрен гарәп-фарсы сүзләре белән чуглаган ярым госманлы телендә язды.* М. Гали. *Без бу турыда бер ел соң белдек.* Г. Гобәй.

2. Диалогта: „алайса“; „шулай булгач“; „нәтиҗә ясап әйткәндә“ дигәнне һ. б. ш. белдерә. [*Хәлим:*] *Минем дә шул төшем авырткан иде.* [*Әтисе:*] *Соң, төзәлдеме?* И. Гази. [*Карты:*] *Соң, карчык, чүпрәк булгач өр-яңа була димени инде?* Г. Гали. || *җөмлә форм.* Сөйләүченең төп фикерен, соңгы сүзен көтүне чагылдырып, „моның белән нәрсә әйтергә телисез“; „максатыгыз нәрсә“; „сүзегездән нинди нәтиҗә чыга“ дигәнне белдерә. [*Рәйхан:*] *Мин аның белән сөйләштем.* [*Бибкәй:*] *Соң?* [*Рәйхан:*] *Ул үзе дә укырга китәргә булды.* Н. Исәнбәт.

3. *с. мәгъ., хәб. функ.* Гадәттәгедән кичеккән, тиешле чиктән узган (вакыт турында).— *Ник, вакыт әле шулкадәр үк соңмыни?* Г. Камал. *Бер-ике стакан кайнар чәй булганда баш тартмас идем дә бит, вакыт соң инде.* М. Шабай.

4. *и. мәгъ. кыек форм.* Ахыр, тәмамланыш; нәтиҗә. *Соңга таба Галимә апа шушы чалмалы кешеләрнең --- тырнаклары астында изелгән сымак булып күзләрен йомды.* М. Гафури. *Башта чибәр генә, дөрес кенә итеп башлап киткән татар көйләрен соңына таба инде Камил әфәнде [боза].* Ф. Әмирхан. *Тыңлагыз, аяныч тарихның соңы бик гыйбрәтле.* Э. Еники. *Озак төннең соңында яктырып ал таң ата.* Татар поэзиясе антологиясе.

◇ **Соң дәрәҗәдә** — бик, аеруча. *Ул бүген көн буе шәһәрнең бөтен урамнарын кырыштырып үзенә бүлмә эзләп йөргән вә шунлыктан соң дәрәҗәдә*

арган иде. Ф. Әмирхан. *Юлга чыккан вакытта соң дәрәҗәдә күңеле төшенке булган Нәсимәнең дә күңеле күтәрелеп китте.* Ш. Камал. **Соңга калу** — соңгару, кичегү. [*Вәли:*] *Я, ярар, аларын башка вакытта сөйләшербез, театрга барырга соңга калабыз, бар, тизрәк бул!* Г. Камал.

СОҢ II *чыг. килеш. бәйл.* Берәр нәрсә яки кеше артыннан; берәр нәрсә тәмамлангач яки узгач. *Ишектән олылардан соң чыгу. Йокларга балалардан соң яту. Яңгырдан соң тузан басылу. Кичке аштан соң саф һавада йөреп керү.* □ *Кырын эш кырык елдан соң да беленә.* Мәкаль. *Җыеннан соң озак тормады, халык арыш урагына төште.* М. Гали. *Уку өендә эше беткәннән соң, Зиннәт кайтырга чыкты.* Г. Бәширов.

СОҢ III *кис.* Тойгылы җөмләләргә көчәйтү төсмере өсти. *Читен дә соң читкә киткән чакта.* М. Җәлил. *Дәбәт тә соң безнең як!* Ф. Хөсни. *Әмма соң бу кыш көне бигрәк уңайсыз.* Г. Тукай. *Зәйнәп! Күлмәгең әмма матур булд соң!* Дәрдмәнд.

СОҢАЮ *ф. диал. к.* соңгару (1 мәгъ.). *Җәйләр ерак әле. Кояш көн дә Бик соңаеп эшкә уяна.* М. Җәлил. *Вакыт шактый соңаеп бара. --- Күзләрне инде йокы да баса башлады.* С. Рафиков.

СОҢГАРУ *ф.* **1.** Тиешле вакыттан кичегү, сроктан артка калу. *Яз соңгару. Явым көнне уракны соңгарып башлау. Кич чыккан яшьләрнең кайвакыт соңгарып кайтуы. Транспорт җайлы туры килмәү аркасында мәҗлескә соңгару.* □ *Иргали быел мәдрәсәгә соңгарып кына килеп җитте.* Ә. Фәйзи.

2. Узган вакытны әзрәк, кимрәк итеп күрсәтү; артка калу (сәгать турында). *Сәер ашкыну бар миндә: Көтәм дигәндә иркәм, Сәгатем соңгара дим дә Өч сәгать алдан китәм.* З. Нури.

СОҢГЫ *с.* **1.** Бер әзлеклелектә торган нәрсәләр тәртибендә: иң ахырга туры килгән, ахыргы, азаккы. *Газетаның соңгы бите.* □ *Сәгъди бабайның --- өч баласы булып, ике өлкәне кыз, соңгы — кечесе ир бала идг.* Ш. Камал. *Соңгы звонок. Поезд кузгалды.* М. Максуд.

2. Иң ахырга калган. *Соңгы трамвай белән кайту. Соңгы кар эреп бетү. Соңгы көлтәне чүмәләгә салу.* □ *Яраланган егет, суны ярып, Ярга йөзә соңгы көч белән.* Ә. Исхак. *Соңгы тамчы каным тамса тамсын, Тик антыма таплар кунмасын!* М. Җәлил. || Актыккы һәм бердәнбер. *Соңгы патронга кадәр сугышу.* □ *— Бу югалту [әти үлү] минем өчен бигрәк тә зур югалту булды. Мин үземнең соңгы таянычымнан да аерылган кебек хис иттем.* М. Гафури. *Каптагы соңгы шырпыдан көч-хәл белән ут дөрләде.* Б. Камалов. || Соң өлгерә торган (үсемлек турында). *Соңгы сортлар. Соңгы чәчәкләр.* □ *Без ул полоса буйларына соңгы культураларны чәчәргә тырышабыз.* Каз. утл.

3. Күптән түгел генә, моннан алда гына булып узган. [*Гөлсинә:*] *Мин соңгы бер ай эчендә бер генә брак та бирмәдем.* Р. Ишморат. *Киң, тигез юлдан җиңел генә тәгәрәгән автомобиль соңгы җылы яңгырлар белән күтәрелеп киткән басуга килеп чыкты.* А. Шамов.

4. Әле генә дөньяга чыккан; иң яңа. *Журналның соңгы номеры. Соңгы мода белән киенү. Фәннең соңгы казанышлары. Соңгы хәбәрләр.* □ *Кәрим абый алда торган бурычны аңлатты, соңгы күрсәтмәләрне бирде.* С. Сабиров.

5. *кит.* Әле генә искә алынган, иң ахыргы. *Бездә өченче вариант юк. Я безнең тәкъдимне кабул итәсез, яки, чи усак кебек, төрмәдә пыскыйсыз [ди сатылырга өндәүче]. Искәндәр, әлбәттә, соңгысын сайлый.* Г. Гобәй. *Сәүдә эшендәге җитәкче кешегә --- намус белән бергә катыц кул һәм үткен күз дә кирәк икән. Җамалый агайда бу соңгылары җитенкерәмәде.* Г. Минский.

6. Йомгак рәвешендәге, актыккы; катгый, хәлиткеч. *Җыелышта соңгы сүз белән чыгу.* □ [*Хөрмәтулла:*] *Син бик саран кеше икәнсең, каениш. Соңгы сүзеңне әйт.* [*Нургали:*] *Шул, тугыз сумнан кимгә бирә алмыйм.* Т. Гыйззәт. *Күтәрел, ил, дошман өренә, Соңгы көрәш, соңгы давылга!* М. Җәлил.

7. Иң ахырдан һәм гаҗизлектән эшләнә торган (чара һ. б. турында). *Мәдинәнең җан ачулары кузгалды --- һәм соңгы чара итеп кулындагы тал чыбыгы белән бар көченә селтәнде.* Г. Минский.

8. Үлем яки һәлакәт алдындагы. *Үлемгә дип, ачы нәфрәт белән Елмаермын соңгы сулышта.* М. Җәлил.— *Батыр сеңелебезнең соңгы васыяте шундый.* Г. Бәширов. *Сизә, мәлгунь [дошман], соңгы көне җитә.* Ф. Кәрим.

9. Иң түбән, начар, дәрәҗәсез-авторитетсыз.— *Кулыннан килгән бер хезмәтне дә кызганмас һәм безнең арада соңгы кеше булмас ул.* Ф. Бурнаш. *Ул үз милкен үзе урлаучы, иң соңгы, кабахәт кеше.* А. Алиш.

◇ **Соңгы бурыч** — үлем алдындагы яки үлгән кешегә күрсәтелә торган соңгы хезмәт, аның хөрмәтенә эшләнгән соңгы яхшылык. *Йөзләрчә кызылармеец һәм берничә командирга Бикмуш бабайны күмү озакка бармады. Аларның һәрберсе кабергә бер генә уч булса да туфрак салып калырга, шуның белән революция өчен корбан булган бабалары алдында үзләренең соңгы бурычларын үтәргә ашыктылар.* Г. Гобәй. **Соңгы юл** — кабергә озатылу, күмелү турында. [*Үлемгә хөкем ителгән Таһир:*] *Нигә борчылдыгыз Таһир өчен? Мин тынычмын соңгы юлымда.* Ф. Бурнаш. *Ак кәфенгә төрелгән Галиулланы өйдән алып чыктылар. --- Галиулла үзенең соңгы юлына чыкты.* И. Гази.

СОҢГЫЛЫК *и. махс.* Кешедә һ. б. имезүчеләрдә ана карынындагы яралгының тышчасы: бала белән бергә яралып, аны ана тәне белән тоташтыра һәм шул рәвешле аның тукланuын, матдәләр алмашуын тәэмин итә торган өрган; плацента.— *Кулларымны юып авыруга ярдәм бирергә тотындым. Ул бала тапкан. Ләкин соңгылыгын алмыйча калдырганнар. Мин тиешле ярдәмне күрсәттем.* Г. Кутуй.

СОҢЛАУ *ф. к.* соңгару.—*Көтә-көтә зарыгып беттем, чәем дә суынды инде, ни эшләп бу кадәр соңладыгыз?* Һ. Такташ. *Һидият шәһәрдән бер көнгә соңлап кайтты.* Ш. Камал.

СОҢРА *рәв. диал.* **1.** Соңыннан, ахырдан. *Кем эшлекле, кем эшлексез идеке соңра мәгълүм булыр.* Ш. Мөхәммәдев. *Берничә сәгатькә йорт тынып та, соңра тагы ялчылар атлар, чаналар белән кайнаша башладылар.* Г. Ибраһимов.

2. *баш һәм чыг. килеш. бәйл. функ.* Соң. *Өч-дүрт бүре берсе соңра кача берсе, Өченчесе, аннан соңра дүртенчесе...* Г. Тукай. *Шуннан соңра ул ашау-эчү, намаз-нияз вә башканы --- сөйләде.* К. Нәҗми.

СОҢЫНДА *бәйл.* Берәр эш-хәлдән, вакыттан соң, шул узгач. *Нәгыймә үзе катнашмаган бу эшләрнең соңында идәннең, бүлмәнең чүп-чарын җыеп, себереп йөри.* Г. Ибраһимов. *Һәр михнәт соңында Рәхәтле көн дә бар.* Г. Тукай. *Бигрәк тә теге остабикәне куып чыгарганның соңында динче халыклар аны [Фатыйманы] күрә алмый башладылар.* К. Рәхим.

СОҢЫННАН *рәв.* **1.** Бераз вакыттан соң; ахырдан. *Наданлык белән эшләнгән эшкә соңыннан үкенәсең.* М. Гафури. *Мин ул егетнең кем икәнлеген соңыннан гына белдем.* А. Әхмәт.

2. *бәйл. функ.* Берәр кеше яки нәрсәдән, берәр эш-хәлдән соң. *Килер апрель соңыннан безгә майлар,*

Бирер һәркемгә ләззәт ошбу айлар. М. Гафури. *Нинди язмыш мине каршы алыр хәзер чиккән михнәт соңыннан.* Ф. Бурнаш.

СОҢЫНТЫН *рәв. сөйл. к.* соңыннан (1 мәгъ.). — *Нәрсәләр сөйләшкәнне соңынтын әйтермен әле.* Ш .Камал.— *Нигә хат язып кына булса да соңынтын хәбәр итмәдең?* Г. Бакиров.

СПАРТАКИА'ДА *и.* Төрле спорт төрләре буенча һәм киң масса катнашында үткәрелә торган ярыш. *Җәйге спартакиада. Профсоюз спартакиадасы. Заводлар спартакиадасы. Укучылар спартакиадасы. Спартакиадага катнашу.*

СПАРТАКИА'ДАЧЫ *и.* Спартакиадага катнашучы.

СПЕКТАКЛЬ *и.* Театр, сәхнә тамашасы. *Спектакльгә катнашу. Авыл клубында бәйрәм алдыннан үзешчәннәрнең спектакль куюы.* □ — *Сез, Зөфәр абый, спектакльгә караганда концертны ярата төшәсез, ахрысы.* Ш. Камал. *Язучы театрда күрсәтү өчен пьеса яза, икенче төрле әйткәндә, спектакль тудыру өчен әдәби әсәр иҗат итә.* Ф. Хөсни. *Мин кергәндә Гәүһәр телевизор каршында утыра иде. Мәскәүдән спектакль тапшыралар икән.* Л. Ихсанова.

СПЕКТР *и.* Яктылык нурын махсус призма аша сындырып үткәргәндә барлыкка килә торган төс сызыклары. *Яктылык спектры. Спектрның төп төсләре.* || Ут хәленә җитеп кызган җисемнең яки матдәнең нурларын махсус оптик корал аркылы үткәргәндә төшә һәм шул җисемнең яки матдәнең химик составын чагылдыра торган төс сызыклары. *Кояш спектры. Натрий спектры. Водород спектры.* □ *Спектраль анализга килсәк, моны яклаучылар металл әйберләрнең спектрларын тикшерү дәвамында аларның составын --- гына түгел, шул металл әзерләгән руданың кайдан табылып, кайчан эшкәртелүен өйрәнә икән.* М. Госманов.

СПЕКТРАЛЬ *с.* Спектрга мөнәсәбәтле. *Спектраль анализ.*

СПЕКТРОГРА'ММА *и. физ.* Спектрның фоторәсеме.

СПЕКТРОСКОП *и. физ.* Спектрларны күзәтү коралы.

СПЕКТРОСКО'ПИК *с.* Спектроскопка, спектроскопиягә мөнәсәбәтле.

СПЕКТРОСКОПИ'Я *и.* Спектроскоп ярдәмендә спектрларны өйрәнү, тикшерү эше.

СПЕКУЛЯНТ *и.* Спекуляция (1 мәгъ.) белән шөгыльләнүче.— *Гомер-гомергә спекулянт булган кешегә үтерсәң дә ышанмыйм.* Ш. Камал. *Спекулянт йөри мыштым гына, Уйлап сине алдау хакында.* З. Мансур.

СПЕКУЛЯНТЛЫК *и.* Спекулянт кәсебе, шөгыле. *Нигездән алып караганда, сәүдәгәрлекнең-спекулянтлыкның советка каршы юл булуын, шуңа күрә ил өчен начар булу белән генә чикләнмичә, якын киләчәктә үзең өчен дә бик начар нәтиҗәләр бирү ихтималы барлыгын аңлатырга тиеш идек.* М. Әмир.

СПЕКУЛЯТИВ *с. кит.* 1. Спекуляциягә (1 мәгъ.) нигезләнгән; шуна мөнәсәбәтле. *Спекулятив бәяләр. Спекулятив килешү.* □ [*Капиталистик илдәге*] *товар биржалары спекулятив сәүдә урыны булып торалар.* Политэкономия.

2. Спекуляциягә (2 мәгъ.) нигезләнгән; абстракт. *Спекулятив караш. Спекулятив теория. Спекулятив фраза.* □ *Спекулятив алымнар белән исламның догмаларын һәм инануларын нигезләргә тырышкан дини система ул.* Каз. утл.

СПЕКУЛЯ'ЦИЯ *и.* 1. Киң куллану товарларын һ. б. нәрсәне, табыш калдыру өчен, үзең алганнан кыйбатрак бәягә сату эше; жинаять. *Спекуляция өчен судка тартылу. Алпавытларның җир белән спекуляция ясавы.* □ [*Мөршидә Мәхмүзәгә:*] *Базарга барып спекуляция ясап йөрисең.* Р. Ишморат. *Сугыш елларында гына спекуляция белән күтәрелгән яңа байларны Бикмөхәммәтев теләнче байлар дип йөртә иде.* Ш. Камал.

2. Танып белүдә тойгыларның һәм практиканың әһәмиятен инкяр итеп, белем чыганагын мөстәкыйль акылга гына кайтарып калдыручы философик тәгълимат. *Сыйнфый көрәшне инкарь итү яки томалап калдыру--- иң артта калган катлауларның, вак хуҗачыкларның наданлыгыннан һәм хорафатларыннан файдаланып спекуляция ясау.* В. И. Ленин. [*Табигатьне бөлдерү бәрабәренә колхоз доходын арттыру турындагы*] *мәкалә Идриснең дә кәефен кырган иде. — Ялган бит бу, спекуляция. Иң эшәке ягы шунда — алай түгел икәнлеген моны язган кеше үзе дә белә!* Г. Бәширов.

СПЕЛЕО'ЛОГ *и.* Спелеология белгече, шул өлкәдә эшләүче. *Спелеологлар Көньяк Кыргызстанның Катран тау сыртында җылы пар чыгара торган тау куышы таптылар. --- Куышта кайнар сулы күл бар икән.* Соц. Тат.

СПЕЛЕОЛО'ГИЯ *и.* Тау куышларын, мәгарәләрне (аларның ясалуын, үсешен, төзелешен, таралышын һ. б.) фән һәм спорт-туризм максаты белән тикшерү эше; шуның теориясе-фәне.

СПЕ'РМА *и.* Ир һәм ата хайван органыннан бүленеп чыга торган җенес күзәнәкле матдә.

СПЕРМАТОЗО'ИД *и.* Кеше, хайван һәм күп төр үсемлек организмында: ата җенес күзәнәге.

СПЕЦИАЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Хуҗалыкны, оешманы: бер генә тармак буенча яки тар өлкәдә генә эш алып барырлык итеп үзгәртеп кору; махсуслаштыру. *Халык хуҗалыгын специальләштерү һәм кооперативлаштыру. Ит җитештерүне специальләштерү. Социалистик илләрнең җитештерүен дәүләтара специальләштерү һәм кооперативлаштыру эшләре.* □ *Төзү оешмалары бик нык үзгәртеп корылды, ереләндерелде һәм специальләштерелде.* Соц. Тат.

СПЕЦИАЛЬЛӘШҮ *ф.* Хуҗалык, белгечлек, хезмәт һәм фәннең бер генә төрен, тармагын яки тар өлкәсен сайлап алып, шул юнәлеш белән чикләнү; махсуслашу. *Врачларның специальләшүе. Министрлыклар специальләшү. Дәүләтара специальләшү. Төзү оешмаларының специальләшүе. Хуҗалыкара һәм хуҗалык эчендәге специальләшү.*

СПЕЦИ'ФИК *с. кит.* Берәр тар өлкәгә генә кәраган; үзенчәлекле. *Специфик күренеш. Специфик шартлар. Специфик тармак.* □ [*Муса*] *минем шикелле белмәгән кешегә шактый специфик мәсьәләне дә бик аңлаешлы итеп сөйләп бирә белә иде.* М. Максуд. *Бу мәсьәләдә без нинди ярдәм күрсәтә алырбыз икән соң?! Бик артык специфик мәсьәлә бит.* А. Расих.

СПЕЦИ'ФИКА *и. кит.* Махсус үзенчәлек; үзенчәлекле шартлар. *Эш спецификасы. Сәнгать спецификасы.* □ [*Язучылар*] *заманның идеяләрен, омтылышларын, мәхәббәтләрен һәм нәфрәтләрен формалаштыралар. Әмма алар моны үз сәнгатьләренең спецификасы аша, образлар аша чагылдыралар.* Ф. Хөсни. *Программа барыбызга да бер. Ләкин аны --- тормышка үткәрү өчен җирле специфика белән таныш кешеләр кирәк.* Ш. Усманов.

СПЕЦИ'ФИКАЛЫ *с. к.* специфик.

СПЕЦО'ВКА *и. сөйл.* Махсус эш киеме (гадәттә киемне бик пычрата яки тиз туздыра торган эштәгеләр өчен). *Монтер спецовкасы. Янгынчыларның брезент спецовкасы.* □ *Бер көнне кокс төйибез, икенче көнне электр стансасында шлак түгәбез, өченче көнне тимер юлда ком таратабыз. --- Озакламый спецовка да бирделәр: соры парусин күлмәк белән шундый ук чалбар киеп җибәрдем.* Ш. Маннур.

СПИ'ДОЛА *и.* „Спидола“ маркалы, транзисторлы портатив радиоалгыч.

СПИДО'МЕТР *и. махс.* Автомобиль, мотоцикл һ. б. машинада: йөреш тизлеген һәм узган юлны күрсәтү җайланмасы. *Автомобильнең тизлеген спидометрдан карап бару.*

СПИ'ННИНГ *и.* Очында вак балыкка охшаш, кармаклы ялтыравык алдавыч калай тагылган җебе һәм аны чорный торган кәтүге булган саплы балыкчы әсбабы; ерткыч балыкны тоту коралы. *Тәки котыртты бу мине: алдым ул спиннинг дигәннәрен. Тимер. Сыек тал чыбыгыдай сыгылып-уйнаклап тора. Кәтүшкәсе дә әйбәт. Калган хәтлесен без бергәләп сайлап алдык. Әллә никадәр ялтыравыч: алтындай сарысы, көмештәй агы, кандай кызылы бар.* Э. Касыймов.

СПИРАЛЬ *и.* **1.** Бер нокта яки күчәр тирәли әйләнеп, зурая яки кечерәя барган, йомылмый торган әйләнәләр ясаучы кәкре сызык. || Шундый формалы юнәлеш, әз һ. б. ш. *Тауга менә торган юлның спираль буенча баруы.*

2. Спираль (1 мәгъ.) формалы төрле нәрсә: сызым, рәсем, металл чыбык һ. б. ш. *Электр плитәсенә спираль сатып алу.*

3. *с. мәгъ.* Спираль (1, 2 мәгъ.) формалы. *Спираль сызык. Спираль антенна. Шөрепнең спираль сыры. Спираль баскыч.*

СПИРИТИЗМ *и.* Хорафатчылык: үлгән кеше „җаны“ның теге дөньяда яшәвенә һәм аның белән бәйләнешкә керү мөмкинлегенә ышану.

СПИРИТУАЛИЗМ *и.* Материягә, кеше аңына бәйсез яшәүче „җан“, „рух“ турындагы идеалистик тәгълимат.

СПИРИТУАЛИСТ *и.* Спиритуализм тарафдары.

СПИРО'МЕТР *и. махс.* Сулап чыгарган һава күләмен үлчәү коралы.

СПИРТ *и.* **1.** Янучан һәм исерткеч сыеклык (шикәрле яки крахмаллы матдәләрне махсус куу юлы белән табыла).

2. *махс.* Составында гидроксил төркеме (-ОН) булган органик матдә, углеводород. *Бер яки күп атомлы спирт. Этил спирты.*

СПИРТЛАУ *ф.* **1.** Спирт (1 мәгъ.) катнаштыру. *Виноград эчемлеген спиртлау.*

2. Бозылмый саклансын өчен, спирт сеңдерү, спирт белән эшкәртү яки спиртка салу. *Анатомик музейга куела торган экспонатларны спиртлау.*

СПИРТЛЫ *с.* Составында спирт булган, спирт кушылган (төрле матдәләр, сыекчалар, эчемлекләр һ. б. турында). *Спиртлы лак. Спиртлы эчемлек.*

СПИРТО'ВКА *и. махс.* Спирт яндырып эшли торган җайланма: йомшак, көчсез генә ут чыганагы (лаборатор эшләрдә һ. б. ш. кулланыла).

СПО'РА *и. биол.* **1.** Үсемлек организмында: үрчү органы булган микроскопик бәбәк. *Үсемлекләрнең спора ярдәмендә үрчүе.* □ *Тимергалиев споралар, ягъни гөмбә орлыклары саклана торган махсус бүлмәгә кереп бара. Биомицин цехы уртасындагы өстәл артында микроскопка иелеп [бер кыз утыра].* Г. Галиев.

2. Иң түбән төзелешле хайваннарда: яралгы.

СПОРТ *и.* Физик күнегүләр белән шөгыльләнү эше (организмны, саулыкны ныгыту, шулай ук ярышларда җиңүгә ирешү максатын күздә тота). *Физкультура һәм спорт белән шөгыльләнү. Кышкы спорт төрләре. Яшьләр спорты. Спорт уеннары. Мәктәпнең спорт секциясе. Спорт ярышына катнашу. Чаңгы спорты. Спорт җәмгыяте.* □ *Дсгать спорт ярата. Ул футбол командасы члены.* М. Максуд.

СПОРТЗАЛ *и.* Спорт күнегүләре ясый һәм ярышлар үткәрә торган махсус зал, бүлмә. *Завод клубындагы спортзал.* □ *— Озакламый өлгертеләчәк утыз икенче номерлы йортта спортзал җиһазлыйсы бар.* З. Нури.

СПОРТЧЫ *и.* Спорт белән шөгыльләнүче. [*Егеттә*] *сабырлык һәм яшерен көч сизелеп тора иде: гәүдәсе нык, төз; күрәсең, спортчы булган.* Г. Әпсәләмов. *Якшәмбе көнне меңләгән спортчылар кросс дистанцияләренә чыктылар.* Соц. Тат.

СПРА'ВКА *и. сөйл.* Язма белешмә, документ. *Врач справкасы. Авыл советы справкасы.* □ *— Әгәр доктордан „эшләргә мөмкин“ дигән справка китерсәң — эшлисең, юк икән, мин сиңа эшләргә рөхсәт итмим.* Р. Ишморат.

СПРИ'НТЕР *и.* Йөгерешү, йөзешү, коньки яки велосипед белән узышу кебек ярышларның кыска дистанцияләреннә катнашучы спортчы.

СПРУТ *и. к.* сигезаяк.

СРОК *и.* **1.** Билгеле бер вакыт арасы; вакыт. *Армия хезмәтенең срогы тулу. Берәр эшне башкарып чыгу өчен срок билгеләү. Ике айлык срок. Кыска срок. Срокның чикләнгән булуы. Сынау срогы. Ял йортында икенче срокка калу.* □ *— Унбиш көн срок эчендә Кучәрбайны да укырга-язарга өйрәт.* М. Әмир. *— Ярышның срогы иртәгә тула.* Ә. Фәйзи.

2. Берәр нәрсәнең килеп житү, башкарылу вакыты. *Чәчү срогын кичектермәү.* □ *— Рәхмәт, иптәшләр. Намус белән эшләп срогына өлгертүегез өчен рәхмәт.* Т. Гыйззәт.

СРОКЛЫ *с.* **1.** Срогы билгеләнгән, кыска вакытлы; шул срок дәвамында үтәлеп бетәргә тиешле. *Сроклы эш.*

2. Билгеле срокка гына алынган, шул срок дәвамында гына эшләргә тиешле. *Сроклы эшче.*

ССУ'ДА *и махс.* Килешенгән срокта кайтару шарты белән дәүләттән, хуҗалык оешмаларыннан һ. б. ш. җирдән алына-бирелә торган бурыч (гадәттә акчалата). *Дәүләттән ссуда бирелү. Ссуданы вакытында түләү. Чәчү орлыгы ссудасы. Өстәмә ссуда. Колхозларда озак сроклы ссуда фондлары булдыру.* □ *Соңгы елларда гына күп [кешеләр] --- ссуда алып йорт салдырдылар.* Ә. Еники.

СТАБИЛИЗА'ТОР *и. махс.* **1.** Очкыч һ. б. аппаратларда: үзәкнең даими торышын саклау, тотрыклылык бирү җайланмасы. *Очкыч стабилизаторы. Автомобиль стабилизаторы. Мина стабилизаторы.* □ *Парашют белән сикерергә туры килде. Сикергән чакта стабилизаторга бәрелгәнмен ахрысы, аңымны җуйганмын. Ниндидер бер ят землянкада исемә килдем.* Г. Ахунов.

2. Берәр зурлыкның (мәсәлән, электр тогының) даимилеген саклауга хезмәт итә торган җайланма. *Радиотехникадагы ешлык стабилизаторы. Көчәнеш стабилизаторы.*

СТАБИЛИЗА'ЦИЯ *и. кит.* Стабильләшү күренеше, барышы һәм хәле. *Экономик стабилизация. Стабилизация чоры башлану.* □ *Капитализмның вакытлыча стабилизациясе елларында Германия империализмы Америка кредитлары ярдәме белән үзенең экономик куәтен кайтарды.* КПСС тарихы.

СТАБИЛЬ *с. кит.* Даими бер хәлдә торган; тотрыклы. *Стабиль дәреслекләр һәм мәктәп программалары. Стабиль стандартлар. Стабиль бәяләр. Экономиканың стабиль булуы.* □ *Химик элементлар ике төрле яши: берәүләре стабиль, таркалмый; икенчеләре исә радиоактив, бертуктаусыз таркала.* Соц. Тат.

СТАБИЛЬЛЕК *и. кит.* Стабиль булу сыйфаты, хәле һәм дәрәҗәсе. *Хәлнең стабильлеге. Экономик буталчыклыктан арынгач, капиталистик дөньяның*

чагыштырмача стабильлек чорына керүе. □ *Ярдәмлекләрнең аерым төрләре (бәйлек һәм теркәгечләр) фонетик төзелеш стабильлекләрен дә нык саклыйлар, үз тирәләрендәге сүзләрнең гармониясенә һич тә буйсынмыйлар.* В. Хангилдин. *Ритмнан, стабильлектән бер чыккан технологик агым барыбер кысасына кермәде.* Каз. утл.

СТАБИЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Стабиль хәлгә, формага китерү. *Экономиканы стабильләштерү. Политик хәлне стабильләштерү. Стандартларны, нормаларны стабильләштерү. Сүзләрнең язылышын стабильләштерү.*

СТАБИЛЬЛӘШҮ *ф. кит.* Даими тотрыклы, стабиль хәлгә килү; шул хәлдә ныгу. *Илнең экономик һәм политик хәле стабильләшү. Орфография кагыйдәләре стабильләшү. Дәреслекләрнең һәм программаларның стабильләшүе. Бәяләр стабильләшү.* □ *Хәзерге әдәби телебездә җыр рәвешендә стабильләшкән сүз Тукай теленда җыр һәм җыру рәвешләрендә очрый.* Ш. Рамазанов.

СТА'ВКА *и. хәрби.* **1.** Гаскәр башлыгы (яки аның штабы) урнашкан урын. *Ставканы күчерү.*

2. Сугыш вакытында: иң югары командование органы. *Ставканың боерыгын үтәп, төнге караңгылыкта гаскәрләр ашыгыч рәвештә бер урыннан икенче урынга күченде.* Г. Әпсәләмов.

СТАВРИ'ДА *и. зоол.* Алабугасыманнар отрядыннан вак диңгез балыгы.

СТАДИАЛЬ *с.* Стадиягә мөнәсәбәтле, шуны чагылдыра торган. *Стадиаль теория.*

СТАДИОН *и.* Спорт күнегүләре, ярышлары үткәрү һәм тамашачылар утыру өчен урыннары булган махсус корылма яки мәйданчык. *Мәктәп стадионы. Җәйге стадион. Ябык стадион.* □ *Ял көне һәм өстәвенә авиация бәйрәме булганга, стадион тулы халык иде.* М. Максуд.

СТА'ДИЯ *и.* Берәр нәрсәнең үсеш-үзгәрешендә, берәр процесста: яңа үзенчәлекле баскыч, чор. *Үсешнең түбәнге һәм югары стадияләре. Чирнең башлангыч стадиясе. Капитализмның соңгы стадиясе.* □ *— Мин әйткән ысул тәҗрибә стадиясеннән чыкмаган әле. --- Аннары фәнни тәҗрибә яки ачыш гамәлгә керсен, эшкә ашсын өчен күпмедер вакыт кирәк.* А. Тимергалин.

СТА'ДИЯЛЕ *с.* Билгеле баскычлар, чорлар аша үтә торган, чорларга бүленгән (үсеш-үзгәреш һ. б. ш. турында). *Стадияле үсеш теориясе. Стадияле процесс.*

СТАЖ *и.* **1.** Берәр өлкәдә эшләү, берәр оешмада, җәмгыятьтә тору вакытының күләме. *Пенсияне гомуми стажданчыгып билгеләү. Укытучылык стажы зур булу. Партия, комсомол, профсоюз стажы.* □ *Мөслимованың хатын-кызлар арасында эшләү стажы зур булса кирәк, политикага да бик оста булып чыкты.* Г. Иделле.

2. Эшкә өйрәнү, күнегү, үзеңне лаеклы күрсәтү һ. б. ш. өчен кирәк булган яки рәсми билгеләнгән вакыт, срок. *Сынау стажын үтү. Партиягә кергәндәге кандидатлык стажы.*

СТАЖЁР *и.* Стажировка үтүче. *Колхозның йөк машинасында стажер булып йөрү.*

СТАЖЁРЛЫК *и.* Стажер вазифасы, хезмәте. *Ул төпчек улы Михаилны Иванга стажерлыкка бирергә киңәш итә. Атасы кебек тынгысыз, техниканы үлеп яратучан Михаил мондый тәкъдимне дүрт куллап каршы алган.* М. Хөсәен.

СТАЖИРО'ВКА *и.* Берәр эшкә керешер, билгеләнер алдыннан күнекмә, тәҗрибә алу өчен махсус сроклы сынау үтү. *Стажировкада булу. Стажировка срогын кыскарту.* □ *Әгәр Роберт озын сроклы стажировкадан соң бәхәсле мәсьәләләр күтәрә ала икән, бу инде бик шәп — фәнни стажировка үз нәтиҗәсен биргән дигән сүз.* М. Госманов. *Хәзәр алар [курсантлар] үз колхозларында стажировка үтәләр.* Соц. Тат.

СТАЖЛЫ *с.* Берәр өлкәдә чагыштырмача озаграк эшләгән, берәр оешмада, җәмгыятьтә озаграк торган; стажы күп булган. *Шахта җимерелү аркасында күптән эшләп килгән эшчеләрнең байтагы эшсез калганда, стажлы эшчеләр кул астында эшләгән минем кебек яшь кешенең эшсез калуы бик мәгълүм һәм табигый иде.* М. Гафури. *Аның бригадасындагылар бары да тәҗрибәле, стажлы слесарьлар.* А. Расих.

СТА'ЙЕР *и.* Озын дистанцияле (ерак аралы) узыш ярышларына катнаша торган спортчы. *Йөгерешче стайер. Конькичы стайер. Мотоциклчы стайер.*

СТАКАН *и.* **1.** Су эчү, су алу-салу һ. б. ш. өчен кулланыла торган, цилиндр формалы, сапсыз, үтә күренмәле пыяла савыт. *Кырлы стакан. Юка пыялалы стакан. Бизәкле стакан.* □ *— Бөрәр стакан чәй эчеп алырга кирәк.* Г. Минский.

2. *техн.* Стакан (1 мәгъ.) формалы җайланма. *Хәдичә саварга хәзерләнә башлады. Әмма аппарат стаканнарын кулына алу белән бу уйдан кире кайтты.* М. Хәсәнов.

СТАКАНЛАП *рәв.* Стакан белән (ага-түгелә, чәчелә торган нәрсәне алу-салу, эчү һ. б. ш. турында). *Җиләкне стаканлап сату.*

СТАКАНЛАУ *ф. сөйл.* Стакан белән үлчәү (бөртекле нәрсәне һ. б. ш.). *Чикләвек стаканлау.*

СТАКАНЛЫ *с.* **1.** Стакан эчендә булган, шуңа салынган. *Стаканлы сөт.*

2. Стакан белән үлчәнгән; әз. *Стаканлы чикләвек.*

СТАЛАГМИТ *и.* Тау куышларында һ. б. ш. урыннарда: известь һ. б. минераллар катнашкан су тамудан барлыкка килеп, сөңге яки очлы багана рәвешенә кереп каткан минераль утырма.

СТАЛАКТИТ *и.* Сталагмит сыман, ләкин куышның түшәменнән асылынып торган минераль утырма.

СТАН I *и.* Металлны басым белән эшкәртү машинасы яки машиналары системасы. *Рельс, калай, торба прокатлау станы. Кызган корыч кисәкләрен станда эшкәртеп нечкәртү, сузу, таптату.* || Төрле эш башкару өчен корылган (гадәттә агач) җайланма. *Тәгәрмәч кыру, сугу, тарттыру станнары. Үсемлек мае чыгару, ат дагалау, каплату станнары. Типография станы. Кызларның тоташтан өчәр стан киндер сугуы. Киндер станын келәткә кору.* □ *Ишек алдына эреле-ваклы түгәрәк чарлар беркетелгән станын күтәреп кайракчы керде.* К. Нәҗми.

СТАН II *и.* Авылдан ерак басуларда эшләүчеләр өчен күчмә өе, кайвакыт ярдәмче каралтылары да булган вакытлы торак урыны. *Бригада станы. Станда җыелыш үткәрү.* □ *Мансуров урман буена урнашкан кыр станына — карт юкә агачларына ышыкланып утырган салам түбәле ике тәрәзәле зур келәткә таба китте.* Г. Бәширов. || Ерак басуда эшләүчеләр өчен эшләнгән күчмә өй. *Трактор станы. Тәгәрмәчле стан.*

-СТАН Кушма сүзләрнең ахыргы кисәге буларак, шундый ил, дәүләт дигәнне белдерә, мәсәлән: **Татарстан, Һиндстан.**

СТАНДАРТ *и.* **1.** Бер үк төр нәрсәләр өчен: норма итеп алынган үрнәк, өлге. *Дәүләт стандарты. Халыкара стандартлар. Стандартны үзгәртү яки яңарту. Товарның стандартка туры килүе. Авырлык стандарты. Йорт төзелешендә берничә стандарт куллану. Стандартларның искерүе.* □ *— Заводтан эре ташлы бетон җибәрәләр. Безнең стандарт буенча, вак ташлы булырга тиеш.* А. Гыйләҗев.

2. *с. мәгъ.* Стандартка (1 мәгъ.) туры килә, җавап бирә торган; билгеле бер стандарт белән эшләнгән. *Стандарт ферма биналары. Стандарт йортлар.*

3. *с. мәгъ. күч.* Киң таралган төргә караган, бердәй булган. *Кешеләр стандарт түгелләр. Бер уйда, бер фикердә йөргән кешеләр арасында да характерда, башкада аерымлык була.* Г. Кутуй. || *шелт.* Бер формада катып калган, искереп тәэсирлелеген һәм иҗадилыгын югалткан, туйдырып бетергән (фикер, сөйләм һ. б. ш. турында). *Стандарт алым. Стандарт фраза.* □ [*Элек*] *хатларны гарәп-фарсы сүзләре белән чуарланган стандарт формаларда язалар һәм яздыралар иде.* И. Гази.

СТАНДАРТЛАШТЫРУ *ф.* Стандартка туры китерү. *Заводта эшләнә торган әйбер төрләрен стандартлаштыру. Детальләрне стандартлаштыру. Төзелешне стандартлаштыру. Стандартлаштыру институты.*

СТАНДАРТЛАШУ *ф.* **1.** Стандартка туры килү, стандарт буенча җитештерелә башлау.

2. *күч.* Шул бер формада катып калу, искереп иҗадилыгын югалту, шаблонга әйләнү (фикер, сөйләм һ. б. ш. турында).

СТАНДАРТЛЫК *и.* Стандарт буенча эшләү алымы. *Бер үк жанр эчендәге мондый төрлелек, әлбәттә, бик зур байлык: димәк, талантларның үзенчәлеге тулысынча ачыла дигән сүз. Юкса безне бит стандартлыкта гаеплә үләре бар; әнә карагыз, укыгыз: бездә стандарт фикерләүчеләр дә, стандарт форма белән генә яшәүчеләр дә юк.* И. Гази.

СТАНДАРТСЫЗ *с.* Тиешле стандартка туры килми торган, стандарт буенча эшләнмәгән; яраксыз яки сыйфатсыз. *Төзелешне тапшырганда --- шактый гына стандартсыз тимер-бетон плитәләр калган. Кем кайтарткандыр аларны.* А. Гыйләҗев.

СТАНИ'ЦА *и.* СССРның әлекке казачийлар яшәгән җирләрендә: зур авыл. *Станица атаманы. Дон, Урал буе станицалары. Хезмәт иясе депутатларының станица советы.* □ *Станица тимер юлдан унбиш-егерме чакрымлап читтә торганлыктан, кызыл разведчикларның бирегә кадәр килеп чыгуларын уйлаган кеше юк иде. Аларның көпә-көндез казачий станицага һөҗүм итү ихтималы берүнең дә башына сыймады.* Ш. Усманов.

СТАНОВОЙ *и. сөйл. к.* становой пристав. *Авылга становой килеп, алтынчы елда казна урманын кисүчеләрне суктыртты.* К. Нәҗми.

Становой пристав — патша Россиясендә: өяз полициясе башлыгы.— *Сөләйман бай өенә становой пристав килгән, берегез дә калмый җыенга барыгыз! — дип, халыкны таяклап җыенга куа башладылар.* М. Гафури.

СТАНОК *и.* **1.** Металл яки агач эшкәртә, берәр нәрсә эшләп чыгара торган машина, җайланма. *Токарь станогы. Типография станогы. Металл кыручысу, агач эшкәртү станоклары.* □ — *Якын көннәрдә тагын салам, печән турый торган станоклар кайтачак.* Г. Әпсәләмов. *Алдагы зур бүлмәдә, итек басучылар кебек, гади кул станогы белән йон тетүчеләр --- эшлиләр иде.* М. Гали.

2. Пулемет, туп һ. б. ш. нәрсә урнаштырып беркетелгән нигез. [*Шаяхмәт*], *бер якка каерылып төшкән пулеметының станогын алып, каршысына килгән фрицны бер селтәүдә сугып екты.* А. Әхмәт.

СТАНОКЛЫ *с.* Станогы булган; станокка беркетеп куелган. *Станоклы пулемет.*

СТАНОКЧЫ *и.* Станокта эшләүче эшче. *Аның бригадасына йөздән артык станок беркетелгән. Йөз станокчыда йөз сорау. Станокны төзәтүгә караганда ватылудан саклау, әлбәттә, җиңелрәк. Шуңа күрә җиһазларның төзеклеге турында кайгырту, вакытында профилактика ясау — ремонтчыларның әһәмиятле бурычы.* Соц. Тат.

СТАНСА *и. сөйл. к.* станция. *Бу җирләрдә озак калсаң да, кире стансага кайтсаң да, жандарлар тозагының бер ятьмәсенә элгүең бик* [*ихтимал*]. Г. Ибраһимов.

СТА'НЦИЯ *и.* **1.** Тимер юлда һ. б. ш. җирдә: тукталыш урыны һәм шундагы корылмалар. *Станциядә поезд көтү. Товар поездлары станциясе. Станция дежурные. Метро станциясе. Автобус станциясе.* □ *Зур станция иде бу. Һәр якта поездлар тезелешеп тора.* Г. Гобәй. *Станциянең юллары бушап калды.* Ш. Усманов.

2. Кайбер дәүләт, хуҗалык оешмалары, җәмгыятьләр һ. б. ш. исеме. *Тәҗрибә станциясе. Насос станциясе. Телефон станциясе. Көймә станциясе. Яшь натуралистлар станциясе. Метеорологик станция.* □ *Якты Күлдә һәм кайбер колхозларда электр станцияләре, кирпеч заводлары салынды.* Г. Бәширов. *Менә Арчы кошчылык станциясенә авыл өчен чыннан да гажәп булган яңа машина килә.* Г. Иделле.

СТА'ПЕЛЬ *и. махс.* Суднолар төзү, ремонтлау һәм суга төшерү өчен ясалган авыш мәйданчык. *Команда килеп җиткәндә „Татария“ төзелеп беткән һәм стапельдән суга төшерелгән иде инде. Кабул итү сынаулары вакытында --- яңа теплоходны бик җентекләп өйрәнделәр.* С. Сабиров.

СТА'РОСТА *и.* **1.** Октябрьга кадәрге авылда: идарә итү һәм җәза бирү вазифаларын башкару өчен сайлап яки билгеләп куела торган кеше. *Авыл старостасы.* □ [*Урядник:*] *Без сине староста итеп куймакчы булабыз.* [*Дәүли:*] *Минем бит грамотам юк. Кул да куя белмим.* [*Урядник:*] *Каракларны, мошенникларны, патша законына тел тидерүчеләрне вакытында хәбәр итеп торсаң, безгә шул җитә.* Т. Гыйззәт.

2. Берәр кечерәк коллективта, җәмгыятьтә: оештыру эшләрен башкару өчен сайлап яки билгеләп куела торган кеше. *Класс старостасы. Курс старостасы (институтта һ. б.). Артель старостасы. Чиркәү старостасы.* □ *Ул драма түгәрәгенең старостасын күрде һәм, берсе көнгә дип, репетиция сәгатен билгеләде.* Г. Кутуй.

СТАРОСТАЛЫК *и.* Староста хезмәте һәм вазифасы. *Старосталыктан баш тарту.*

СТАРТ *и.* **1.** *спорт.* Узыш ярышларында: башлангыч момент, башланыш. *Стартка хәзерләну.* || Очкыч аппаратның күтәрелеп китү моменты. *Очкычларның старт көтүе. Ракетаның старт мәйданчыгы.* || Узыш ярышын башлау яки очкычның күтәрелеп китүе өчен бирелә торган сигнал, команда. *Старт булганнан соң узышучыларны күзәтү. Пистолеттан атып старт бирү.*

2. Узыш ярышларында: башлап, кузгалып китү урыны, сызыгы. *Чаңгы ярышында башта малайларның стартка чыгуы.* || Очкыч күтәрелеп китә торган урын. *Самолетны стартка кую.* □ *Самолет стартка табан борылды. Без дә аның артыннан киттек. Стартка барып җиткәч, инструктор үз янына безнең группа старшинасын чакырып алды.* С. Баттал.

СТА'РТЕР *и.* **1.** *к.* стартчы. *Узыш башлана. Стартер һәр өч секунд саен трассага чаңгычы озатып тора.* Соц. Тат. [*Өйрәнчек очучы:*] *Кузгалып киттем дә, яңадан туктап, кулны күтәрдем. Шуңа җавап итеп стартер миңа ак флаг күтәрде.* С. Баттал.

2. Эчке янулы двигательләрдә: моторны кабызу механизмы яки җайланмасы. *Стартер ачкычы.* □ *Ул кабинага кереп утырды, кабина ишеген шапылдатып япты да стартерга басты.* Н. Фәттах.

СТАРТЧЫ *и.* Старт сигналын, командасын бирүче. *Иртәгә старт биреләсе дигән көнне „Восток-6“ корабы командиры, инде урнашкан традиция буенча, стартчылар белән очрашты. Космик гигантны очышка хәзерләүче кешеләрне монда әнә шулай дип атыйлар.* Соц. Тат.

СТАРШИНА *и.* 1. Совет Армиясендә һәм Хәрби диңгез флотында: кече команда составына бирелә торган иң югары хәрби дәрәҗә; шул дәрәҗәне алган кеше.

2. Октябрьга кадәр: берәр сословиеле оешманың, профессиональ төркемнең идарә-оештыру эшләрен башкарү өчен сайлап куела торган кеше. *Цех старшинасы.* □ *Дежурный — клуб старшиналарыннан берәү.* Г. Камал. *Гыйлаҗиның кече малае приемда утыра торган старшина Садыйкның кызын җәйдән бирле яучылап йөри.* М. Гали.

СТАРШИНАЛЫК *и.* Старшина хезмәте һәм вазифасы. *Бу авыл һәр яктан да тирә-якка мәркәз: анда зур мәдрәсә дәвам итә, волостьның идарәсе дә шунда тора, һәр сайлауда диярлек старшиналыкка да бу авылның байларыннан берсе элгә.* Г. Ибраһимов.

СТАТИК *с.* 1. Статикага (1—2 мәгъ.) караган, тигезлек саклауга мөнәсәбәтле. *Статик теория. Статик басым.*

2. *кит.* Хәрәкәтсез, үзгәрешсез, торгын. [*Тормыш*] *— туктаусыз үзгәреп, алмашынып торган бер диңгез. Шуңа күрә пролетариат әдәбиятында статиктан бигрәк динамик моментлар зур урын алалар.* Г. Ибраһимов.

СТАТИКА *и.* 1. Механиканың бер тармагы: җисемнәрдә тигезлек саклану законнарын тикшерә.

2. Физикада: төрле көчләр тәэсирендә җисемнең тигезлек саклавы, аның тигезлек хәле. *Каты җисем статикасы. Сыеклык яки газ статикасы.*

3. *күч.* Эш-хәрәкәт юклык, үзгәрешсезлек, торгынлык хәле. *Тормышыңда статика булмау.*

СТАТИСТ I *и.* Сүзсез рольдә чыгыш ясаучы артист.

СТАТИСТ II *и. к.* статистик II.

СТАТИСТИК I *с.* Статистикага мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Статистик тикшерүләр. Статистик материал. Статистик механика. Статистик физика.* || Статистикага нигезләнгән. *Статистик метод. Статистик таблица.* □ *Шигырь турында сөйләгәндә салкын статистик саннарга нигезләп кенә фикер йөртү урынлы микән?* М. Әмир. || Статистика эшләре белән шөгыльләнә торган. *Статистик бюро. Статистик идарә.*

СТАТИСТИК II *и.* Статистика белгече. *Статистиклар хәзерләү курсы. Статистик булып эшләү.* □ *Дөрес, әлегә кулда статистиклар, экономистлар санап чыгарган быелгы төгәл саннар юк. Шулай да, һич икеләнмичә шуны әйтергә кирәк, без быел ашлыкны былтыргыдан ким алмадык.* Азат хатын.

СТАТИСТИКА *и.* 1. Иҗтимагый һ. б. күренешләрне сан-микъдар ягыннан гомумиләштереп тикшерү-өйрәнү фәне. *Институтта статистика курсын уку.*

2. Иҗтимагый һ. б. күренешләрнең гомумиләштерелгән микъдари исәбе, учеты; саннар белән күрсәтелгән исәп-хисап мәгълүматлары. *Рәсми статистика. Халык саны турындагы статистика.* □ *Фабрикантларның стачкалар --- турындагы статистикасын китерәбез.* В. И. Ленин.

3. Күп кенә төгәл фәннәрдә (мәсәлән, физика, механика, астрономиядә) кулланыла торган фәнни тикшеренүнең махсус алымы. *Математик статистика. Квант статистикасы.*

СТАТОР *и.* Электр машинасында: хәрәкәтчел, әйләнә торган кисәк (ротор) белән берлектә эшләүче хәрәкәтсез, әйләнми торган кисәк. *Турбина статоры.*

СТАТС-СЕКРЕТАРЬ *и.* 1. Октябрьга кадәрге Россиядә: патшага хезмәт күрсәтүче югары дәрәҗәле сарай түрәләренә бирелгән почетлы исем. || Дәүләт советы каршындагы Дәүләт канцеляриясенең бүлек башлыгы.

2. Кайбер Көнбатыш илләрендә: югары дәрәҗәле хезмәткәрләрнең яки министрларның рәсми исеме.

СТАТУС *и. махс.* Берәр шәхеснең-затның, оешманың һ. б. ш.: хокук хәле. *Дипломатик статус. Дәүләтнең бәйсезлек статусы. Совет хөкүмәтенең Көнбатыш Берлинга ирекле шәһәр статусы буенча турындагы проектлары.*

СТАТУС-КВО *и.* Халыкара хокукта һ. б. ш.: билгеле бер вакыттагы хәл, торыш. *Статус-кволы саклау.*

СТАТУТ *и.* 1. Берәр нәрсәне үтәү-башкару яки куллану турындагы кагыйдәләр җыентыгы. *Оккупация статуты. Юридик статут. Дан ордены статуты.* || Берәр оешманың һ. б. ш. төзелеш принципларын һәм эш тәртибен билгели торган устав. *Берләшкән Милләтләр Оешмасы статуты.*

2. Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә: закон, хөкүмәт боерыгы яки дәүләтнең законнар җыентыгы. *Король статуты. Парламент чыгарган статут.*

СТАТУЭТКА *и.* Вак скульптур сын, гадәттә бүлмәне бизәп тора торган кечкенә һәйкәл. *Спортчы статуэткасы.* □ *Ул китапларга исе китмичә генә карады. --- Аның каравы, статуэткалар аның күзен кыздырды.* Г. Әпсәләмов.

СТАТЬЯ *и.* 1. Берәр юридик документта һ. б. ш. рәсми кәгазьдә: тәртип номеры белән күрсәтелгән мөстәкыйль бүлекчә, параграф. *Халыкара килешү статьяларын яхшы белү. Законның теге яки бу статьясын дөрес аңлату. Устав статьясы.*

2. Финанс документының, бюджетның керем-чыгым төрен күрсәткән бер бүлекчәсе, параграфы. *Бюджет статьялары. Культура чыгымнары статьясы.* □ *Директор, бирешергә теләмичә, формаль сәбәпләр китерә башлады: ягъни, законсыз эшләп [эшчегә йорт салып биреп] булмый, статьясы юк аның.* Ә. Еники.

СТАЦИОНАР *с.* 1. Оешмасы, төзелеше, урыны даими булган, күчмә түгел. *Стационар театр. Стационар госпиталь. Стационар кино.* || Берәр җирдә даими яки озак булуга, торуга мөнәсәбәтле. *Институтның стационар бүлеге. Диспансердагы стационар бүлек.*

2. *кит.* Үзгәрешсез, даими. *Җисемнең стационар хәле.*

3. *махс.* Хәрәкәтсез, бер урынга беркетеп куелган, күчереп йөртелми торган. *Стационар аккумулятор.*

4. *и. мәгъ.* Вакытлы яки күчмә булмыйча, даими эшли торган дәүләт оешмасы, бүлек һ. б. *Стационарда дәваланып яту. Стационарга укырга керү.* □ [*Кыз:*] *Читтән торып консерватория тәмамлыйсы бар.* [*Өйләнешеп шәһәргә китәргә тәкъдим итүче егет:*] *Стационарда укырсың.* Б. Камалов.

СТАЧКА *и. к.* забастовка. *Политик яки экономик стачка. Гомуми стачка. Докерлар стачкасы. Стачка комитеты. Стачка кассасы.* □ *Иваново-Вознесенскида 1905 елның май аенда башланган забастовка җитмеш ике көнгә сузылды. --- Иваново-Вознесенск эшчеләренең стачкасына Шуя, Орехово-Зуево һәм башка шәһәрләрнең текстильчеләре дә кушылды.* КПСС тарихы. *Фабрикаларда, заводларда, бишенче елдагы кебек, стачкалар дулкыны җәелеп бара иде. --- Җир астында алтын казучы алты меңләп эшче, --- эш ташлап, дирекция конторасына бараллар.* К. Нәҗми.

СТА'ЧКАЧЫ *и.* Стачкага катнашучы. *Фабрикант әфәнделәр стачкачылар санын киметеп күрсәтүләрен үзләре үк исбат иттеләр.* В. И. Ленин.

СТЕАРИН *и.* Аксыл яки саргылт төстәге, ярым үтә күренмәле май сыман матдә: шәм, сабын ясау һ. б. ш. өчен файдаланыла. *Стеарин табы.*

СТЕЛЛАЖ *и.* Күп катлы шүрлек сыман җайланма. *Библиотекадагы китап стеллажлары. Складтагы товар стеллажлары. Торф киптерә торган стеллажлар.*

СТЕЛЛАЖЛАУ *ф.* Стеллажлы итү, берәр урында стеллаж ясау. *Эш бүлмәсен стеллажлап җиһазлау. Стенаны стеллажлау.*

СТЕЛЛАЖЛЫ *с.* Стеллажы булган, үзенә стеллаж ясап куелган. *Стеллажлы бүлмә. Стеллажлы стена.*

СТЕН *и.* Механикада: көч үлчәү берәмлеге.

СТЕНА *и.* **1.** Бина, каралты һ. б. ш. ян кормасы: эчке өлешне тыштан (атмосфера һ. б. тәэсиреннән) аерып-каплап һәм түбәне күтәреп тору, шулай ук бүлмәләр-бүлемнәр ясау хезмәтен үти. *Өй стенасы. Сарай стенасы. Умарта стенасы. Таш стена. Кое стенасы. Стена бүрәнәсе. Калын стена.* □ *Түр һәм сул як стена буйлап --- ике чаршау корылган.* М. Фәйзи. *Вагон стеналарына плакатлар да ябыштырып куйдык.* К. Нәҗми.

2. Ныгытма хезмәтен үти торган койма сыман корма-корылма. *Кремль стенасы. Крепость стеналары. Шәһәр стенасы.*

◇ **Стена газетасы** — кулдан язып яки машинкада басып гадәттә стенага эленә торган җирле (башлангыч) җәмәгать оешмалары (һәм администрацияләренең дә) органы. *Мәктәп стена газетасы. Стена газетасын бәйрәм алдыннан чыгару. Стена газетасындагы тәнкыйть мәкаләсе. Стена газетасының ролен күтәрү.*

СТЕНГАЗЕ'ТА *и. сөйл. к.* стена газетасы.

СТЕНД *и.* **1.** Экспонатлар, диаграммалар, газеталар һ. б. күрсәтмә материаллар урнаштырыла торган күргәзмә җиһазы (гадәттә вертикаль куела торган махсус такта җирлек, аслык); шунда куелган материаллар. *Халык хуҗалыгы күргәзмәсенең стендларындагы экспонатларны алыштырып-яңартып тору. Ял паркындагы стендларны карап йөрү. Ватан сугышы стенды. Тукай әсәрләре буенча эшләнгән стенд. Социалистик ярыш стенды.*

2. Машина, аппарат кебек коралларны җыю-сынау өчен махсус җиһазланган урын яки җайланма. *Җыю стенды. Автозавод стендлары. Станок сынау стенды.* □ [*Врач — МТС директорына:*] *Эшчеләр талап итүенә карамастан, моторлар сынауны махсус стендларга күчерү турында да кайгыртмагансыз.* Г. Әпсәләмов.

СТЕНОГРА'ММА *и.* Стенография белән язылган текст, язма. *Съезддагы чыгышларның кыскартылган стенограммалары. Утырыш стенограммасы белән танышу. Стенограмма уку.*

СТЕНОГРА'ФИК *с.* Стенография (1 мәгъ.) өчен булган, шуңа мөнәсәбәтле. *Стенографик алфавит. Стенографик билгеләр.* || Стенография белән язылган. *Стенографик отчет. Стенографик язма.*

СТЕНОГРАФИСТ *и.* Стенографик ысул белән язу остасы, белгече.

СТЕНОГРАФИСТКА *и.* Хатын-кыз стенографист. *Безгә бик әйбәт стенографистка табып бирелде; --- конференцияләрдәге чыгышларны бөтен күңелен куеп, җентекләп язып барды ул һәм пөхтә итеп төплап китерде.* Г. Ахунов.

СТЕНОГРА'ФИЯ *и.* **1.** Тиз язып барырга мөмкинлек бирә торган махсус хәрефләр (билгеләр) системасы; шул хәрефләр белән тиз язу ысулы. *Стенографияне белүче журналист. Стенографияне камилләштерү.*

2. Шул язу системасы һәм аны өйрәнү-өйрәтү турында фән. *Университетта стенография укыту. Стенография дәреслеге. Татар стенографиясе.*

СТЕНОГРА'ФИЯЛӘҮ *ф.* Стенография белән язу (докладны, чыгышны һ. б.).

СТЕРЕО- Алынма кушма сүзләрнең „пространство әчендәге", „күләмле", „стереоскопик" дигән мәгънәле беренче кисәге, мәсәлән: **стереометрия, стереография, стереотелевизор, стереоэкран, стереофильм, стереофотография, стереохимия.**

СТЕРЕОКИНО *и.* Күләмлелек, ераклык-якынлык тойгысы бирә торган кино. *Стереокино экранындагы кошларның залга очып чыгар кебек тоелуы.*

СТЕРЕОМЕ'ТРИК *с.* Стереометриягә мөнәсәбәтле. *Стереометрик мәсьәлә.*

СТЕРЕОМЕ'ТРИЯ *и.* Элементар геометриянең пространство фигураларын тикшерә торган тармагы.

СТЕРЕОСКОП *и.* Ике яссы сурәтне бергә кушып, кабарынкы, күләмле итеп күрсәтә торган оптик аппарат.

СТЕРЕОСКОПИ'Я *и.* Стереоскопик кино яки фото ярдәмендә күләмлелек тойгысы бирә торган сурәтләр эшләү.

СТЕРЕОТИП *и.* **1.** Типографиядә җыелган текстның металл, резина яки пластмассага төшерелгән, кабатлап бастыру өчен кулланыла торган копиясе. *Стереотип хәзерләү. Стереотип матрицалары.*

2. *с. мәгъ.* Шушы копияне кабатлый торган, шул басмадан үзгәрешсез басылган (китап һ. б. турында). *Стереотип басма. Стереотип экземпляр.*

СТЕРЕОТИПЧЫ *и.* Стереотиплар хәзерләүче типография эшчесе. *Аның басмаханәсендә татарлар арасыннан югары квалификацияле җыючылар, басу һәм төплләү осталары, литография эшчеләре, хәреф кисүчеләр, хәреф коючылар, стереотипчылар күпләп җитешә.* И. Рәмиев.

СТЕРЕОФО'НИК *с.* Стереофониягә нигезләп эшләнгән. *Стереофоник радиоалгыч. Стереофоник кино.*

СТЕРЕОФОНИ'Я *и. махс.* Авазны чыгарып яки кабат яңгыратып, аның таралу юнәлешен һәм чыккан урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул; шул рәвешчә пространствода аваз чыгару-яңгырату.

СТЕРИЛИЗА'ТОР *и.* Стерильләү, йогышсызландыру аппараты, җайланмасы. *Стерилизаторда хирургик коралларны кайнату.*

СТЕРИЛИЗА'ЦИЯ *и.* Стерильләү процессы һәм эше. *Хирургик операция коралларына стерилизация үткәрү.* □ *Алар күксел лампалар яктырткан бүлмә аша үттеләр. Монысы стерилизация өчен, һәр төрле микроб-бактерияләрне юк итү өчен эшләнә икән.* А. Тимергалин.

СТЕРИЛИЗА'ЦИЯЛӘҮ *ф. к.* стерильләү. [*Яраны тегәргә дигән җепне*] *кайнаттылар, медицина кушканча стерилизацияләделәр.* Ш. Бикчурин.

СТЕРИЛЬ *с. махс.* Стерильләнгән. *Стериль мамык.* □ *Сөлек тешләгән урынны стериль бинт белән бәйлиләр.* Азат хатын.

СТЕРИЛЬЛӘҮ *ф.* **1.** *махс.* Кайнату, кыздыру, химик эшкәртү яки бүтән юл белән берәр нәрсәнең тере микроорганизмнарын бетерү. *Хирургик операция коралларын стерильләү. Сөтне стерильләү. Төрле нурлар яки кайнар пар ярдәмендә стерильләү.*

2. *мед.* Хирургик операция ясап, кешене яки хайванны ясалма рәвештә орлыксызландыру.

СТЕ'РЛИНГ *и.* Британиядә: алтын һәм көмеш акча стандарты. *Стерлинг зонасы.* □ *Унтугызынчы елның язында --- Америка долларлары һәм Англия стерлинглары исәбенә оештырылган һәм өйрәтелгән гаять зур армия Себердән Волга буена таба* [*юнәлде*]. Соц. Тат.

СТЕТОСКОП *и.* Йөрәкне, үпкәне тыңлый торган махсус көпшә, медицина коралы. *Сулышны һәм йөрәк тибешен стетоскоп белән тыңлап тикшерү.* □ [*Врач*] *кесәсеннән стетоскобын чыгарып егетнең күкрәгенә куйды һәм берничә урыннан тыңлады.* А. Шамов.

СТИЛЕТ *и.* Нечкә пычаклы кечерәк кинжал.

СТИЛИСТ *и.* Стиль I (2 мәгъ.) сәнгатенә ия булучы, шуның остасы (язучы, редактор һ. б. ш. турында).

СТИЛИ'СТИК *с.* Стильгә (2 мәгъ.), стилистикага мөнәсәбәтле. *Телнең стилистик чаралары. Стилистик алымнардан уңышлы файдалану. Укучының стилистик ялгышларын төзәтү. Стилистик пландагы фәнни тикшеренүләр.*

СТИЛИ'СТИКА *и.* **1.** Тел һәм сөйләм стильләре турындагы тәгълимат. *Татар теле стилистикасы. Стилистика укыту.*

2. *җый.* Тел һәм сөйләмнең тулаем стиль чаралары. [*Персонажлар*] *берсе дә үзләре сөйләмиләр, алар өчен автор үзе сөйли. Автор уйлавы, автор сүзләре, автор стилистикасы.* Ф. Хөсни.

СТИЛЬ I *и.* **1.** Сәнгатьтә: билгеле бер чорның, юнәлешнең яки аерым авторның иҗат эшчәнлегенә һәм формасына хас булган үзенчәлекләр, билгеләр. *Архитектурада Көнбатыш яки Көнчыгыш стильләре. Сынлы сәнгать стильләре. Музыка стильләре. Әдәбияттә романтизм стиле.* □ *Залның гомуми күренеше бик гади, җиһазы чуар — бер генә стильдә түгел, күзгә бәрелеп торган әллә ни байлык һәм купшылык юк.* Ә. Еники. *Татар халык җырлары стилендәге бу шигырь чылтырап аккан чишмә суы шикелле матур һәм тигез ритмлы яңгырый.* М. Максуд. || Берәүнең эш алымнарына, берәр төрле эшчәнлек өлкәсенә хас үзенчәлекләр, билгеләр. *Ленинча эш стиле. Җитәкчелек стиле. Йөзү стильләре.* □ *Масса тәнкыйтен кысарга теләүче, иске стиль белән эш итүче партком секретаре Яруллин, бу хәл өчен ачуланып, башлангыч партоешма секретарен — заман рухын тоеп яшәүче Варис Исламовны бюрога чакыртып тиргә.* М. Әмир.

2. Тел, сөйләм чараларыннан, мөмкинлекләреннән файдалану алымнарының теге яки бу төре һәм шуңа хас билгеләр. *Югары һәм түбән стильләр. Фәнни әдәбият стиле. Эш кәгазьләре стиле.*

СТИЛЬ II *и.* Ел исәбен алып бару ысулы. *Яңа стиль. Иске стиль.* □ *Таныклыкта Җәлилнең туган көне иске стиль белән күрсәтелгән.* Каз. утл.

СТИЛЬЛЕ *с.* Берәр стиль (1 мәгъ.) белән эшләнгән: төзелгән, тегелгән, бизәлгән һ. б. ш. *Стильле кием. Стильле җиһаз. Стильле бизәк.* □ *Йорт әле яңа, тышланмаган, стильле итеп эшләргә уйланылган.* Г. Ахунов.

СТИЛЬЛӘШТЕРҮ *ф.* Үрнәк итеп алынган берәр стильнең билгеләрен, үзенчәлекләрен бирү; шул стильгә туры китерү.

СТИЛЬЧЕ *и. к.* стилист. *Моңарчы тиңе булмаган оста стильче һәм шигъри тойгылы прозаик иде ул. Әгәр Тукай телебезнең иксез-чиксез шигъри сүз байлыгын, аның матурлыгын, тапкырлыгын поэзиядә ачкан булса, шуларны ук Г. Ибраһимов прозада ачты.* Г. Бәширов.

СТИЛЯ'ГА *и. сөйл.* Киенүдә, сәнгатьтә, үз-үзен тотуда һ. б. ш. теләсә нинди кычкырып торган модага ияреп, җәмгыять алдында җаваплылыкны, әдәплелекне онытkан кеше. *Билгеле, стилягалар безгә киемнәре, модалы биюләре һәм җырлары белән генә түгел, кабахәтлек һәм оятсызлык тудырулары белән, паразитларча яшәргә омтылулары белән курkыныч.* Соц. Тат.

СТИ'МУЛ *и. кит.* Берәр эшкә кызыксыну уята торган сәбәп, этәргеч. *Мораль стимул. Хезмәткә материаль стимул.* □ *Татар поэзиясендә яңа жанр тудыруга стимул биргән студиянең эшчәнлеге дә консерватория тирәсендә генә бикләнеп калмады.* М. Максуд.

СТИМУЛЛАШТЫРУ *ф.* Берәр эшкә стимул, этәргеч бирү. *Терлек үрчетүне стимуллаштыру.* □ *Эш хакы озак вакыт буенча --- материаль стимуллаштыруның төп формасы булып калачак.* Тат. ком.

СТИМУЛЯ'ТОР *и. махс.* Берәр нәрсәнең үсешенә стимул, этәреш бирүче матдә. *Организм артык начар шартларга куелса, аның күзәнәкләрендә яшәү өчен көрәш дәвалары — стимуляторлар эшләнә башлый. Бу биологик стимуляторларны тере фабрикада эшләнгән шифалы дару дип атарга була.* А. Расих. *Яңа препарат --- ферма терлекләренә бирелә торган азык рационында, стимулятор буларак, үзенә иң мактаулы урынны алды.* Г. Галиев. || Гомумән, берәр күренешне, хәрәкәтне, эшчәнлекне һ. б. ш. активлаштыра, стимуллаштыра торган чара. *Мораль стимулятор.*

СТИПЕНДИАТ *и.* Стипендия алып укучы. *Стипендиатлар исемлеге. Ленин стипендиатлары.* □ *Институтларда колхоз стипендиатлары күп укый.* Соц. Тат.

СТИПЕ'НДИЯ *и.* Югары яки махсус урта мәктәптә укучыга даими биреп барыла торган акчалата ярдәм. *Дәүләт стипендияләре. Стипендия алып уку.* □ [*Әхтәм*] *бит революция өчен гимназиясеннән куылды. Стипендиядән мәхрүм калды.* Г. Ибраһимов.

СТИХИ'Я *и.* **1.** Борынгы философиядә: табигатьнең төп (ут, су, һава яки җир) элементларыннан берсе.

2. Туктатып, тыеп булмаслык көч рәвешендәге табигать күренеше. *Ут стихиясе. Стихия көчләре.* □ *Авыл тормышы, крестьянның һәр катлавының да эше табигать белән, стихия көче белән бәйләнгән.* Г. Нигъмәти. *Куркыныч һәм шомлы су стихиясе белән көрәшеп эштән чыккан тәнгә --- элекке көче кайтты.* Г. Бәширов.

3. *күч. кит.* Оешмаган, тәртипсез хәрәкәт итә торган иҗтимагый көч турында. *Теориясез практика ул — стихия... Ә стихия ул — кешелек фаҗигасе.* Каз. утл. *Ак офицерлар, кулаклар коткысы белән шактый киң җәелгән ул сукыр стихиягә* [*сәнәкчеләр фетнәсенә*] *каршы сугышка бу тирәләрнең барлык коммунистлары, комсомоллары, алдынгы яшьләре катнашкан.* Ш. Маннур.

4. *күч. кит.* Гадәтләнелгән-күнегелгән көндәлек шартлар, табигый, иҗтимагый чолганыш; мохит. *Фронтка беренче тапкыр килүчеләргә болар* [*сугыш көрелтеләре*] *бөтенләй башкача тәэсир итсә, фронтка кабат әйләнеп кайтучыларда исә таныш стихиягә элегү тойгысын һәм анда тизрәк барып җитү теләген генә тудырдылар.* Г. Әпсәләмов.

СТИХИ'ЯЛЕ *с.* **1.** Стихиягә (2 мәгъ.) караган, шуңа бәйле. *Стихияле көч.* || Стихия (2 мәгъ.) көчләренең хәрәкәте нәтиҗәсендә барлыкка килә торган. *Стихияле бәла-каза (су басу, яшеннән янгын чыгу һ. б. ш.).*

2. Җәмгыять, кешеләр тарафыннан идарә ителмичә, тәртипкә салынмыйча, табигый рәвештә, үзеннән үзе бара, була торган. *Буржуаз илләрдә эшсезлекнең стихияле үсеше.* □ *Капитализм вакытында хезмәт бүленеше стихияле төстә бара, ә социализм вакытында ул аңлы рәвештә тормышка ашырыла.* Соц. Тат. || Оешмаган, дөрес политик җитәкчелеге

булмаган (иҗтимагый хәрәкәт һ. б. ш. турында). *Ярсыган халыкның стихияле чыгышы. Крестьяннарның феодалларга каршы стихияле баш күтәрүләре.* □ *Партия — пролетариатның аңлы өлеше булып, эшчеләрнең стихияле хәрәкәтенә аң кертә.* КПСС тарихы.

СТИХИ'ЯЛЕЛЕК *и.* Стихияле нәрсәләргә хас сыйфатлар. *В. И. Ленин болай дип аңлатты: стихиялелек алдында баш ию эшчеләр сыйныфы партиясен пассив көчкә әйләндерә.* КПСС тарихы.

СТИХИ'ЯЧЕЛ *с. к.* стихияле. *Аның иҗатында революция стихиячел бер көч итеп кенә сурәтләнә.* Ф. Хөсни. *Тайгада булдык. Бу бит без аңлаган мәгънәдәге урман түгел, бәлки үсемлекләрнең ниндидер стихиячел котырынуы!* М. Максуд.

СТИХИЯЧЕЛЕК *и.* Стихияле көчләргә ияруҗәнлек. *Башка күп төрле эшләр башкару белән бергә, большевик Якуплар масса аңындагы стихиячелек күренешләрен җиңәргә, Федюшкиннарны да тәрбияләргә тиешләр иде.* Каз. утл.

СТО'ИК *и.* Стоицизм вәкиле һәм тарафдары.

СТОИЦИЗМ *и.* Борынгы Греция һәм Рим философиясендә: материализм белән идеализм арасында икеләнгән рационалистик юнәлеш.

СТОЛЯР *и.* Төрле агач әйберләр (өй җиһазы һ. б. ш.) ясау-эшләү остасы.

СТОЛЯРЛЫК *и.* Столяр һөнәре һәм осталыгы. *Столярлыкка уку.*

СТОМАТО'ЛОГ *и.* Стоматология белгече; теш һәм авыз-казналык авыруларын дәвалаучы врач.

СТОМАТОЛОГИК *с.* Стоматологиягә караган. *Стоматологик тикшеренүләр. Стоматологик поликлиника.*

СТОМАТОЛО'ГИЯ *и.* Медицинаның авыз, теш, казналык һ. б. шул тирә авыруларын тикшерә торган тармагы.

СТОП-КРАН *и.* Вагонда: поездны кинәт туктату өчен куелган тормоз краны. [*Муса — качарга әзерләнүчеләргә:*] *Бүре чокырын узгач, Кшерка урманы башлана; менә шул ике арада вагоннардагы стопкраннарны ачып, тиз генә тышка сикерегез һәм „лимон" яудыра-яудыра урманга керегез.* Ш. Маннур.

СТРА'ЖНИК *и.* Патша Россиясендә: иң кече дәрәҗәле авыл полицейские. *Авыл эчендә шау-шу купты. Ялан кылычларын селтәп, чапкын атларга атланган ике стражник өйдән-өйгә кереп халыкны куалар: — Лашман хезмәтенә!* З. Бәшири. || Гомумән, ул вакыттагы иң кече дәрәҗәле полицейский һ. б. ш. кораллы сакчы. *Губернатор кушуы буенча университетның ишек-капкаларын бикләделәр. Атлы стражниклар, казачийлар нагайкаларын айкап, кылычларын болгап, урам тулы халык өстенә ташландылар.* К. Нәҗми.

СТРАТЕГ *и.* 1. Сугыш алып бару остасы, стратегия (1 мәгъ.) белгече. *Оборонадан һөҗүмгә күчүне борынгы стратеглар сугышта иң авыр эшләрнең берсе итеп саныйлар.* Ә. Еники.

2. Зур тәҗрибәле, оста политик; иҗтимагый-политик тормышның зур стратегик мәсьәләләрен хәл итәргә сәләтле җитәкче. *Революция стратеглары.*

СТРАТЕ'ГИК *с.* 1. Стратегиягә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Стратегик план. Стратегик инициативаны кулда тоту.* □ *Фронт штабы, бу шәһәрнең стратегик һәм сәяси әһәмиятен аңлагач. Орскины Актүбә белән бергә үз кулында тотарга карар бирде.* Ш. Усманов.

2. Стратегия таләпләренә җавап бирә торган. *Стратегик пункт.* || Стратегиягә хезмәт итә, стратегия максатында файдаланыла торган. *Стратегик разведка. Стратегик авиация. Стратегик лозунг. Стратегик чимал. Стратегик резерв.*

СТРАТЕ'ГИЯ *и.* 1. Зур сугышларга җитәкчелек итү осталыгы; шул турыдагы хәрби фән. *Партизан сугышы стратегиясе. Стратегия остасы булу. Дошман стратегиясе.*

2. Иҗтимагый, политик көрәшкә җитәкчелек итү осталыгы; шул хактагы тәгълимат. *Марксизм-ленинизм стратегиясе белән кораллану.* □ *Чорларга яраклы рәвештә партиянең бурычлары, стратегиясе һәм тактикасы, эшне оештыру формалары үзгәрә барды.* КПСС тарихы.

СТРАТИГРА'ФИЯ *и.* Геологиядә: тау токымнары катламнарын өйрәнә торган тармак.

СТРАТИСФЕ'РА *и.* Җир кабыгының утырма токымнардан гыйбарәт өске өлеше.

СТРАТОНА'ВТ *и.* Стратосферага очучы.

СТРАТОСТА'Т *и.* Стратосферага күтәрелү, очу аэростаты. *Стратостатка утырып күктәге зәңгәрсу болытлардан да югарырак күтәрелгән --- кеше дип уйламагыз; юк, ул аңдый күренекле кеше түгел.* А. Шамов.

СТРАТОСФЕ'РА *и.* Атмосфераның тропосфера өстендәге, югарыгы катлавы. *Нәкъ шул елларда атаклы очучы Владимир Коккинаки, дөньядагы барлык биеклекләрдән дә биегәрәк ашып, стратосфераны айкап төште.* Ф. Хөсни.

СТРАХОВА'НИЕ *и. махс.* Милеккә, шәхси иминлеккә яки саулыкка зыян килгән очракта материаль тәэмин ителүне күздә тотып, махсус дәүләт оешмасына һ. б. ш. урынга регуляр взнос түләп тору. *Иректе страхование. Дәүләт страхованиесе. Милек страхованиесе. Мәҗбүри страхование.* □ *Морза именнесеннән кисәү генә калды. Д нәрсәгә ирештек? Морзабыз элеккесеннән дә шәбрәк итеп таш пулат салдырды. Картлар сөйли: ул хөкүмәттән, янәсе, бик күп итеп страхование акчасы алган.* К. Нәҗми.

СТРАХОВОЙ *с.* 1. Страхованиегә мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Страховой агент. Страховой взнос. Страховой акча. Страховой касса.* □ *Рәшидә апа җәмәгать тәртибендә страховой агент булып эшли икән. Ул, длмәт хәлләрен туйганчы бер сорашырга вәгъдә биреп, страховой эшләре белән китеп барды.* Ә. Маликов.

2. Ихтимал булган зыянны каплау өчен махсус бүлеп куелган, шуңа дип билгеләнгән. *Страховой фонд.*

СТРЕЛЕЦ *и.* XVI—XVII йөзләрдәге Русь дәүләтендә: махсус даими гаскәрдә хезмәт итүче.

СТРЕ'ЛКА *и. махс.* Рельс өстеннән йөри торган транспортны бер юлдан икенчесенә күчерү җайланмасы. *Вагоннар бер юлдан икенче юлга күчкәндә, стрелкалар да дыңгырдашып алдылар.* Э. Касыймов.

СТРЕЛКАЧЫ *и.* Стрелка күчереп торучы тимер юл эшчесе. *Әгәр стрелкачы сизгерлеген югалткан булса, тиз йөрешле пассажир поездының аварияга очравы бәхәссез иде.* Соц. Тат.

СТРЕПТОКОКК *и.* Эренле шешләр һ. б. ш. авырулар китереп чыгаручы бактерия.

СТРЕПТОМИЦИН *и.* Антибиотик даруларның бер төре (туберкулез, үпкә авырулары, бума ютәл, дизентерия һ. б. авыруларга каршы кулланыла).

СТРЕПТОЦИД *и.* Стрептококк авыруларына каршы файдаланыла торган дару (ак яки саргылт кристаллик порошок). *Җәрәхәтнә стрептоцид сибеп бәйләү.*

СТРЕСС *и. кит.* Организмның, бигрәк тә нервларның артык киренкелек хәле. *Авыр акыл хезмәте һәм борчу вакытындагы стресс.*

СТРИХНИН *и.* Бер төр тропик үсемлекнең орлыгыннан алынып, медицинада кулланыла торган, агулы, төссез кристаллик матдә.

СТРОЙ I *и. сөйл.* Хәрби саф. *Стройга тезелү. Солдатларның урамнан строй белән узуы.* □ *Строй бер минутка тынып калды.* Г. Әпсәләмов. *Майор строй каршында рәхмәт белдерә.* И. Гази. || *Кыек килеш форм.* Сугышта турыдан-туры катнашу өчен билгеләнгән гаскәр хезмәте. *Стройга яраклы булу.* □ *„Винтовка тота беләбез. Безне стройга алыгыз. Санитарлыкка бездән картраклар да табылыр әле" дигәч, аларның икәвен дә стройга алдык.* Ш. Усманов.

СТРОЙ II *и.* Җәмгыятьнең, дәүләтнең: төзелеш системасы. *Төрле иҗтимагый стройдагы дәүләтләрнең хезмәттәшлек итүе. Совет строе урнашу. Колхоз строеның җиңүе. Халык демократиясе строе.* □ *Социализм --- капитализмны революцион үзгәртеп кору нигезендә үсеп чыга. Анда әле иске стройның эзләре калган була.* КПСС тарихы.

СТРО'НЦИЙ *и.* Радиоактив изотоплары техникада кулланыла торган химик элемент; көмеш сыман ак, җинел металл.

СТРОФА *и. әд.* Шигырьнең ике яки берничә юлын ритм-рифма һәм эчтәлек ягыннан берләштереп мөстәкыйльләштерә торган берәмлек, кисәк. *Җидешәр юллы строфалар.* □ [*Тукайда*] *икешәр яки дүртәр юллы строфалар гына очрый.* Г. Нигъмәти.

СТРО'ФИКА *и. әд.* 1. Поэтиканың строфалар турындагы тармагы.

2. Шигырьнең строфаларга бүленеше, шул яктан төзелеше. *Әхмәт Исхак, мәсәлән, „Евгений Онегин" строфикасын, аның рифма, ритм калыпларын татар шигъри урнәгендә бирү мөмкинлеген күрсәтте.* Г. Кашшаф.

СТРУК *и.* Такта кебек нәрсәләрнең өстен тигез һәм юка гына итеп юндырып алу өчен, озынча калыпка юнгыч яссы тимер беркетеп ясалган корал; *русчасы:* рубанок. *Тактаны струк белән шомартып кую. Ике куллы струк. Струк тимерен чарлау.* □ *Сары йомычкалар чәчри, струк астыннан чыкканнары тәгәрәп китә.* Ш. Маннур.

СТРУКЛАУ *ф.* Струк белән эшкәртү: тигезләп шомарту. *Түбә такталарының бер ягын гына струклау.* □ *Струкламаган тактадан җил-яңгыр тимәсенгә каккалап куйган лапас кисәге ул.* Г. Ахунов. *Лапас ягыннан чыш-чыш нәрсәдер струклаганмы, ышкылаганмы тавыш ишетелеп тора иде.* Р. Төхфәтуллин.

СТРУКТУР *с.* Структура ягыннан карала торган; эчке төзелешкә мөнәсәбәтле. *Металлның структур формуласы. Туфракның структур үзенчәлекләре. Структур анализ. Структур карта.* □ *Гади һәм кушма җөмлә бер-берсеннән төзелешләре белән генә, ягъни структур яктан гына аерылалар.* М. Зәкиев.

СТРУКТУ'РА *и. махс.* Берәр нәрсәнең эчке төзелеше, өлешләре-кисәкләренең үзара мөнәсәбәтеннән гыйбарәт форма. *Матдәләрнең химик структурасы. Җәмгыятьнең сыйнфый структурасы. Ашламаның туфрак структурасын яхшыртуы. Формуланың структурасы катлаулы булу.* □ *— Оешманың принцибы, структурасы турында дүртәүләп сөйләшербез.* Г. Әпсәләмов. *Басуларда туфрак структурасы биш-ун ел саен үзгәреп тора.* Каз. утл.

СТРУКТУРАЛИЗМ *и.* Тел күренешләрен (мәсәлән, фонемаларны, сүзләрне) аларның үзара мөнәсәбәтләре нәтиҗәсе дип карый торган, асылда формалистик бер лингвистик юнәлеш (XX йөз урталарында һәм нигездә Көнбатышта үсеш алган булган).

СТРУКТУРАЛЫ *с.* Үзенчәлекле структурасы, махсус эчке төзелеше булган. *Үз колхозыбызда гына да әллә ничә төрле орлык, әллә ничә төрле туфрак бар. Берсе ачы аның, берсе төче дигәндәй, берсе структуралы, икенче төрлесе тузан гына.* Г. Бәширов.

СТРУКТУРАЛЬ *с. лингв.* Структурализмга мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Структураль лингвистика. Структураль алымнар.*

СТУДЕНТ *и.* Югары уку йортында яки техникумда укучы. *Университет студенты. Беренче курс студенты.* □ *Фәннәр академиясе филиалы --- каршысында яшел утраучыктай булып бәләкәй бакча күренә. Егерме-утыз еллар элек рабфак студентлары утырткан бакча бу.* Г. Минский.

СТУДЕ'НТКА *и.* Хатын-кыз студент. *Мәктәптә укыганда да, студенткa булгач та Гөлфая безгә һәр вакыт килеп йөрде.* Г. Әпсәләмов. *Казаннан практикага килгән студенткаларның берсе Разия белән таныштым.* Ә. Камал.

СТУ'ДИЯ *и.* 1. Сынлы сәнгать остасының мастерское.

2. Художник, скульптор яки артистлар хәзерли торган мәктәп. *Художниклар студиясе. Театр студиясендә уку.* || Күбесенчә яшь кадрлардан (артист һәм художниклардан) торган, уку һәм иҗат эшләрен бергә кушып алып баручы сәнгать коллективы. [*Муса Җәлил*] *әллә ничә журналның редакторы, булачак опера театрының студиясен төзүче иде.* Г. Ахунов. *Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында, беренче милли студия булып, 1934 елда Татар дәүләт опера студиясе төзелде. Бу студиянең төп бурычы --- татар опера театрына җырчы һәм композитор кадрларын хәзерләү иде.* М. Җәлил.

3. Кинофильмнар эшләп чыгара торган дәүләт оешмасы; киностудия.

4. Радио-телевидение тапшырулары һ. б. ш. өчен махсус җиһазланган бүлмә яки бина (радиостудия, телестудия һ. б.).

СТУ'ДИЯЧЕ *и.* 1. Студиядә (2 мәгъ.) укучы. *Казанга кайткач студиячеләр яшь тамашачы театрында уйныйлар.* Соц. Тат.

2. Студия (3, 4 мәгъ.) хезмәткәре.

СТЮАРДЕ'ССА *и. махс.* Пассажир самолетында, шулай ук диңгез пассажир судносында: бортпроводница. *Стюардесса салонга чыгып хәбәр итте: — Самолет түбәнәя, кадерле иптәшләр!* Ә. Маликов.

СУ *и.* 1. Гөрләвек, елга, күл һәм диңгезләрне бәрлыкка китерә торган сыекча (саф хәлендә — водород белән кислородның химик кушылмасы). *Кое суы эчү. Яңгыр суы. Салкын су белән юыну. Суга бару. Гөлгә су сибү. Су савыты.* □ *Чишмә суы тәмле була.* Н. Баян. *Дә сиңа күкне томалап килгән кара болыт: ул су бөртекләреннән түгелме?* Г. Коләхметов. || Эчемлек итеп файдаланыла торган, составына берәр матдә катнашкан су. *Минераль су. Шифалы су. Газлы су.* □ *Йомырка агы салынган кайнар суны тышта тиз-тиз суытты да, авыру сабыйның хәлсез иреннәрен ачып әз-әз йоттырды* [*әнисе*]. Г. Ибраһимов.

2. Инеш, елга, күл, диңгез һ. б. ш. *Тирән су. Су асты дөньясы.* □ *Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын.* Г. Тукай. *Урманнан чыккан кечкенә чишмә, авылга җитәрәк инешкә кушылып, зур гына суга әйләнеп китә. Суның уң як ярлары куе таллар белән күмелгән.* Ф. Хөсни. *Диңгез дигән су шундый зур, аның очын да, кырыен да күреп булмый.* А. Шамов.

3. Дым, юешлек. *Түбәдән су үтү. Су үткәрми торган плащ. Аякка су үтү.* □ *Солы саламына су үткән.* Г. Бәширов.

4. Үсемлек, хайван, кеше организмының күзәнәкләрендә, тукымаларында һәм куышлыкларында була торган, гадәттә төссез яки саргылт (үсемлектә: аның төсенә карап) сыекча, сүл. *Аш казаны суын алдыру.*

Салам белән каен суы эчү. □ *Алманың әчкелтем татлы суы малайның тел өстенә, тамак төбенә йөгерде.* И. Гази. *Авыз тутырып тугай юасын чәйнисе, авыз суын суыра-суыра кузгалак ашыйсы килде аның.* Ф. Кәрим. *Кабарып чыкканнан соң сытылып суы аккан кулым сыкрап тора.* Каз. утл.

5. *гадәттә тартымлы форм.* Берәр матдәнең суга салып, су кушып ясаган эремәсе. *Керне селте суында юу. Авызны содалы су белән чайкап ташлау.* □ *Ул әле яңа гына сабын суына басып кибәргә куйган мамык пирчәткәсен бәләкләп алды.* Г. Галиев. || Берәр нәрсәнең сыек эремәсе. *Кар суы. Тирес суы.* □ *Күкерт суы ага монда, Тимерне тишә тамчы* [*элекке шахтада*]. М. Сөндекле. || Үзендә кайнатылган, пешерелгән, тозланган, изелгән азык әйберләренең тәме сеңеп, сүле, кисәкчәләре катнашкан сыеклык; сыгынты. *Кәбестә суы. Кыяр суы. Эремчек суы.* □ — *Дөге кайнатып, шуның суын бирерсез* [*чирлә-гән балага*]. Г. Ибраһимов. *Гөмбә суы белән керән суы да эчереп карадылар* [*авыруга*]. Ш. Маннур. *Бер чынаякта өстенә яшькелт су җыелган кефир бар иде.* Г. Афзал.

6. *тартымлы форм.* Үсемлек, җиләк-җимеш сыек-чаларыннан ясаган татлы яки жинелчә исерткеч эчемлек. *Җимеш суы.* □ *Галимә апа уранып кына чәй янына килеп утырды һәм, бераз коймак ашау белән бергә, әни кайнатып биргән карлыган суын эчте.* М. Гафури.

7. *с. мәгъ. хәб. функ. күч.* Аш-су турында: бик сыек.

8. *с. мәгъ. хәб. функ. күч.* Нык юешләнгән, чыланып беткән. *Чокырлардан шуышып килгәнгә, Йончытылган, шинельләр — су.* Ф. Кәрим. *Болытлар җир белән тоташкан. --- Балчык итек һәм ботинка олтаннарына сылана. Шинельләр, бүрекләр лычма су.* С. Шакир. *Күлмәк лач су булган.* К. Нәҗми.

◇ **Су анасы** — әкият-хорафатларга ышанучыларча, суда (күбесенчә елгада) яши торган, хатын-кыз кыяфәтле явыз зат.— *Аһ, харап эш! Су анасы да минем арттан чаба.* Г. Тукай. **Су астына (төбенә) китү** — бату; батып һәлак яки харап булу. [*Давыл*] *туктамаса, безнең су астына китүебез дә бик ихтимал.* Э. Касыймов. *Узган елны бер авыл кешесен аты-ние белән алып китте боз. Узен коткардылар, аты белән чанасы су төбенә китте.* Э. Фәйзи. **Су астына (төбенә) җибәрү** — суга батыру; батырып һәлак яки харап итү. *Комсомолец Могилевич, төшәргә сигнал бирелгәч тә, корабтан сикермәи, корабтагы әйберләрнең берсен дә су төбенә җибәрәсе килми, барысын да коткарып калырга тырыша.* А. Алиш. **Су кабу** — *к.* авызга су кабу.— *Акча турында су кап.* А. Әхмәт. **Су кебек (урынына) эчү** — 1) бик яхшы укый белү. [*Фатима*] *русча һәм мөселманча язуларны, халык тәгъбирәнчә, су кебек эчә иде.* Г. Ибраһимов; 2) бик яхшы белү, нык үзләштергән булу (берәр телне, дәресне һ. б. ш.). *Бик тырыша, хәлфә биргән дәресләрне су кебек эчә идем, шулай итеп күңелне юата идем.* М. Гафури. **Су коену (керү)** — юыну, сафлану һ. б. ш. өчен елга, күл кебек су эченә кереп коену. *Казанкада балалар су коена.* И. Гази. *Бозаулар көткән чакта иптәшләр белән су керергә төшә идек.* Ә. Айдар. **Су кушу** — төрле уйдырмалар һ. б. ш. өстәү (сөйләмгә), күпертеп сөйләү. [*Хөсәен*] *сүзләренә су кушып, күзгә төтен җибәрә башлаган икән.* Г. Мөхәммәтшин. **Су кызы** — 1) әкият-хорафатларга ышанучыларча, суда яши торган, озын чәчле кыз кыяфәтле зат. *Тарат, сеңлем, озын чәчләреңне! Алар тузылып төшсен алдыңа. Шулай килешә сиңа. Су кызыдай Кил дә хәзер минем алдыма, --- Утыр, күлдә шәүләң уйнасын; Узган-барган кешеләр тукталып карап, Су кызы дип сине уйласын!* Һ. Такташ; 2) рус һәм Көнбатыш мифологиясендә: таралып төшеп торган озын чәчле, балык койрыклы, хатын-кыз кыяфәтле зат. *Борынгы Грециядә безнең су аналары шикелле чибәр су кызлары турында легендалар булган, бу су кызларын нимфалар дип йөрткәннәр.* Робинзон әзл. **Суга салу** — 1) суга батырып үтерү, һәлак итү. [*Кыз — Таһиргә:*] *Сөйлә безгә, сине суга салып Кемнәр аердылар иленнән?* Ф. Бурнаш; 2) бәхетсезлеккә, һәлакәткә дучар итү. *Байлык вәгъдә итә бай сиңа, Шул байлыкка күңелең ымсына. --- Син кызыңны суга саласың, Син кызыңны утка атасың.* Э. Ерикәй; 3) тиешсезгә яки бик бәрәкәтсез файдаланып әрәм-шәрәм итү. *Нәсимә дус кызларына ияреп, берәр тиенлек көнбагыш яки сагыз алса, әнисе олыдан кубып тирги иде аны: --- Авыр заманда бер тиенне дә эшкә ярый. Ә син аны суга салып йөрисең.* К. Нәҗми. **Судан коры чыгу** — гаепле булып та, үзеңне аклый алу, җәзасыз котылу. [*Әхмәтҗан*], *башын җәүләргә чыгарып, судан коры чыкмакчы була.* Г. Толымбай. **Сулар (су) агу** *шигъ.*— вакыт, гомер узу. *Заман кичте, сулар акты, Хәзер юк инде ялкын; Кызу сүнде йөрәктә, Мәңгелеккә инде ул салкын.* Г. Тукай. *Ул шушы авылдан соңгы тапкыр чыгып киткәннән бирле байтак су аккан булса да, Сөләйманов бөтенесен дә бүгенге кебек хәтерли.* И. Гази. **Сулар (су) кичү** *юг.*— тормыш кыенлыкларын кичерү, жиңеп чыгу. *Йөр, әйлән бөтен җирне, сулар кич; Кеше атлы еланнар калмасын һәм!* С. Рәмиев.

СУАЛЧАН *к.* селәүчән.

СУБ- Кушма сүзләрдә түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәк: 1) берәр нәрсәнең, җирнең астында яки янында, буенда, янәшәсендә, мәсәлән: **субарктик, субстратосфера, субтропик** һ. б.; 2) буйсынган, кая да булса караган, мәсәлән: **субинспектор, субординатор, субконтинент** һ. б.

СУБАИ *и.* 1. Гадәттә сулы-сазлы җиргә яки йомшак нигезгә салынган каралты-корылмаларны күтәреп тора торган багана, терәк. *Күпергә субай сугу. Зур йортларны субай өстенә салу.* □ *Язгы ташу буаның субайларын, тегермәннең куласаларын --- алып китте.* А. Гыйләҗев. [*КамАЗның*] *кою заводында августта алтмыш, ә сентябрьдә өч йөзгә якын субай эзерләнде.* Каз. утл.

2. *с. мәгъ.* Субайлап эшләнгән, шулар өстенә салынган (фундамент, нигез турында). *Ул Ангарада һәм Урта Азиядәге төзелешләрдә катнашкан. Биредә* [*КамАЗда*] *ул субай фундаментлар мастеры булып эшли.* Каз. утл.

СУБАЙЛЫ *с.* Субайлап эшләнә, шуның өстенә корыла-салына торган. *Субайлы күпер. Субайлы буа. Заводның нигезен субайлы итеп эшлә́ү.*

СУБАЙЛЫК *и.* 1. Субай өчен диелгән яки шуңа яраплык булган материал. *Күпер янына субайлык кайтарып ташлау.*

2. *с. мәгъ.* Субай өчен диелгән яки шуңа яраплык, җитәрлек булган. *Субайлык агач.*

СУБАЙЧЫ *и.* Субай сугу-кагу эшендә эшләүче. [*Завод фундаментын салучы*] *субайчыларның түгәрәк сан — ике йөз меңенче субайны сукканда да мәшәкатьләре җитәрлек булды.* Каз. утл.

СУБОРДИНА'ЦИЯ *и. махс.* Дәрәҗәсе кече булганнарның өлкәннәргә рәсми буйсыну системасы. *Субординация саклау.*

СУБСИ'ДИЯ *и. кит.* Гадәттә дәүләт тарафыннан җирле власть органнарына, фирмаларга, аерым кешеләргә яки чит дәүләтләргә бирелә торган акчалата яки натуралата ярдәм. *Төзелешкә бирелгән субсидия. Хәрби субсидияләр.*

СУБСИДИЯЛӘУ *ф.* Субсидия бирү. *Театрны субсидияләү.*

СУБСТА'НЦИЯ *и.* Марксизмга кадәрге философиядә: барлык нәрсәнең үзгәрмәс асылы. *Материаль субстанция. Рухи субстанция.*

СУБСТИТУТ *и. кит.* Берәр нәрсәнең алмашы, аны алмаштырып кулланылырдай предмет. *Синтетик каучук — табигый каучукның субституты. Аваз субститутлары.*

СУБСТРАТ *и.* 1. *махс.* Төрле нәрсәләрнең гомуми, уртак нигезе, бер иш күренешләрнең уртаклык (яки охшашлык) нигезе. *Психик күренешләрнең материаль субстраты. Туфракның минераль субстраты.*

2. *лингв.* Бүтән телгә күчкән халыкның телендә элекке, үз теленнән калган күренешләр. *Субстрат теориясе.*

СУБТРО'ПИК *с.* 1. Тропик буендагы, шуның янәшәсендәге (географик урын турында). *Субтропик илләр. Азербайҗанның субтропик зоналары.*

2. Шундый өлкә, урын өчен хас. *Субтропик климат. Субтропик үсемлек. Субтропик эсселек.*

СУБЪЕКТ *и.* 1. Философиядә: дөньяны танып белүче һәм үзгәртеп коручы зат; кеше. *Кешенең тормышка, субъектның объектка мөнәсәбәтен революцион практика рәвешендә аңласак кына, тарихта шәхеснең ролен дөрес аңлаган булырбыз.* Г. Нигъмәти.

2. Логикада: хөкем йөртелә, сыйфатлана торган нәрсә. *Хөкемнең субъекты һәм предикаты.*

3. *сөйл.* Кире сыйфатларга ия булган, күңелгә ошамаган, шикле кеше турында. *Аерым субъектлар [эшкә] комачаулый икән — аларны юлдан алып ташларга гына кирәк.* А. Расих.— *Я, менә сөйләштегез, ничек соң шул субъект?* Н. Исәнбәт.

СУБЪЕКТИВ *с.* 1. Кеше аңында яши торган, субъектка (1 мәгъ.) гына хас. *Субъектив категория.* || Субъектка, шәхескә, аерым кешегә яки кешеләргә мөнәсәбәтле. *Тарихта субъектив факторларның роле. Җинаятьнең субъектив ягы. Эштәге үзеклекнең субъектив сәбәпләре.* || Берәр кешенең үзенә генә хас; уртак яки гомуми түгел; шәхси. *Субъектив караш, фикер. Субъектив бәя.* □ *Теге яки бу идеяне формалаштыруда аның [язучының] субъектив аерымлыклары шиксез зур бер роль уйный.* Һ. Такташ. *Тарихыбызны бер яклы, субъектив аңлатуга --- килешмәүчәнлек күрсәтергә тиешбез.* Каз. утл.

2. Субъективизмга мөнәсәбәтле, шуңа караган. *Субъектив идеализм. Социологиядәге субъектив метод.*

СУБЪЕКТИВИЗМ *и.* 1. Философиядә: объектив чынбарлыкны инкяр итүче, аны субъект аңында гына яши дип санаучы идеалистик юнәлеш.

2. *к.* субъективлык. *Хәбир папкасын кочаклады да, яраткан остазына үпкәләп, аны субъективизмда гаеплән, кайтып китте.* Ш. Хөсәенов.

СУБЪЕКТИВИСТ *и.* Субъективизм тарафдары. *Субъективистларның тарихта массалар ролен инкяр итүе.*

СУБЪЕКТИВИСТИК *с.* Субъективизмга һәм субъективистка мөнәсәбәтле. *Фактларны субъективистик рәвештә аңлау һәм аңлату. Фикер йөртүдәге субъективистик алымнар. Тарихка субъективистик караш.*

СУБЪЕКТИВЛЫК *и.* Субъектив булу хәле, күренеше; субъектив шәхескә һ. б. ш. хас сыйфатлар. *Хөкемнең субъективлыгы. Фактларны бәяләүдәге субъективлык. Фәндә субъективлыкка каршы көрәшү.* □ *Дәрәҗәгә бәя биргәндә кайбер субъективлыктан арынса, алар [тәнкыйтьченең мәкаләләре] безнең әдәби хәрәкәттә үз ролләрен уйнарлар.* Каз. утл.

СУБҮЛӘР *и. махс.* Ике яки берничә елга бассейннары арасындагы калку урын; *русчасы:* водораздел.

СУВЕРЕН *с. кит.* Тулысынча бәйсез, мөстәкыйль (дәүләтләр һ. б. ш. турында). *Суверен дәүләт. Союздаш республикаларның суверен хокуклары.*

СУВЕРЕНИТЕТ *и. кит. к.* суверенлык. *Социалистик лагерьның бердәмлеге — һәр социалистик илнең милли бәйсезлегенә һәм суверенитетына ышанычлы гарантия.* КПСС тарихы.

СУВЕРЕНЛЫК *и. кит.* Тулы бәйсезлек һәм мөстәкыйльлек (дәүләтләр һ. б. ш. турында). *Октябрь социалистик революциясенең җиңүеннән соң ук Совет властеның декретлары белән халыкларның тигезлеге һәм суверенлыгы игълан ителде, барлык милли һәм башка өстенлекләр һәм чикләүләр бетерелде.* Тат. ком. *Бөтендөнья социалистик системасының барлыкка килү һәм үсеш процессы суверенлык, тулы ирекле лек нигезендә --- бара.* КПСС программасы.

СУГАН *и.* Әчкелт тәмле бүлбесе һәм көпшәле кыягы булган яшелчә яки шуның бер төбе (бүлбесе яки кыягы). *Суган утырту. Яшел суган. Башлы суган. Ашка суган тураү. Кыр суганы.*

◇ **Суган сату** — файдасыз сүз сөйләп вакыт әрәм итү; ләчтит сату. [*Гайнулла карт:*] *Печән базарына чыгып суган сатып, гайбәт сөйләгән кебек булмас әле. Аз булса да шушындый вакытта агай-энегә мәслихәт кылышып, булышканның савабы булыр.* Ш. Мөхәммәдев. **Суган суы суыру** — ачлы-туклы яшәү, ачыгу.— *Алар хәзер суган суы суырып утыралармы?* Һ. Такташ.

СУГАНЛАНУ *ф.* Бүлбеләре барлыкка килү (суганның). *Яшел суганның суганлана гына башлаганда тәмле булуы.*

СУГАНЛАП *рәв.* Суган салып-кушып. *Тураган бәрәңгене суганлап кыздыру. Суганлап пешергән өчпочмак.*

СУГАНЛАП-БОРЫЧЛАП *рәв.* 1. Суган белән борыч салып-кушып. *Суганлап-борычлап әзерләгән салат.*

2. *күч.* Бик каты һәм кискен (тәнкыйтьләү-шелтәләү һ. б. ш. турында). *Суганлап-борычлап сүгү.* □ *Каенана чигенмәде, кайткач та суганлап-борычлап улына хат язды.* Г. Гобәй. *Гасыйм абый --- кешенең йөрәгендә бер әз калдырырлык итеп суганлап-борычлап сөйли дә үзеннән бер нәтиҗә чыгарып куя.* Х. Садрый.

СУГАНЛЫ *с.* 1. Суган утырткан, суган үстерелә торган. *Суганлы түтәл.* || Суган уңган, суган уныйлы булган (ел турында). *Быелгыдай суганлы елны да суган бәясе күтәрелмәс инде.* Сөйләмнән.

2. Суганы булган; суган салган-төягән. *Суганлы капчык, йөк.*

3. Суган салган-кушкан, шуны кушып әзерләгән. *Суганлы бәлеш, салат, шулпа.*

СУГАНЛЫ-БОРЫЧЛЫ *с.* 1. Суган белән борыч салып-кушып әзерләгән. *Суганлы-борычлы бәрәңге, пилмән, шулпа.*

2. *күч.* Бик каты һәм кискен (тәнкыйтьле-шелтәле сөйләм, сүз һ. б. ш. турында). *Суганлы-борычлы сүзләр белән әрләү. Суганлы-борычлы мәкалә белән чыгу. Суганлы-борычлы хат язып салу.*

СУГАНЛЫК *с.* Суган алырга дигән яки шуңа җитәрлек (акча турында).

СУГАНЧА *и. бот.* Үсемлектә: суган бүлбесе рәвешле тамыр. *Кайбер чәчәкне суганчадан үстерү.*

СУГАНЧЫ *и.* Суган үстерүче яки шуның белән сату-сәүдә итүче.

СУГАРГЫЧ *и.* Сугару (1—3 мәгъ.) җайланмасы. *Су кирәгенчә генә ага торган чүлмәк сугаргычлар куела [фермада].* А. Расих.

СУГАРУ *ф.* 1. Су сибү; суга, дымга туендыру. *Борма елга җәйге кырда Чәчәкләрне сугара.* Ә. Ерикәй.

Сугарган ул [елга] иркен болыннарны, Азык биргән язгы гөлләргә. М. Максуд.

2. Дымлы шартлар булдыру өчен, каналлар, арыклар һ. б. ш. үткәрү, төзү. *Чүлләрне сугару.*

3. Су әчертү (хайваннарга).— *Үгезләрне сугардыңмы?* М. Гафури. *Рацион да сусыл азыклар да булса, аларны [терлек] сугарганчы ашаталар.* А. Расих.

4. *күч.* Берәр төрле идея, караш рухын бирү, шуңа буйсындыру. *Дсәрне сыйнфый рух белән сугару.* □ *Ш. Камал үз иҗатын бөтен кешелек көрәше мотивлары белән сугарып, аны күп телдәге совет әдәбиятының бер кисәге итә алды.* М. Җәлил. *Безнең якты матур теләкләрне Партия акылы сугара.* Ә. Ерикәй.

5. *махс.* Кыздырганнан соң ук суыту юлы белән ныклыгын арттыру (металл әйберләрнең). *Тимерчеләр, иске чалгы билен бөгеп [чакма тимере ясап], сугарып, чыныктырып бирделәр.* А. Гыйләҗев.

СУГАРУЛЫ *с.* **1.** Сугарып игелә торган.— *Сугарулы кәбестә утыртасы иде бу дымлы үзәннәргә.* Тат. яшь.

2. Үсемлекләрне сугарып кына иген үстереп була торган, сугарганда гына файдаланырга мөмкин булган (басу, җир турында). *Сугарулы кырларда дөге, кукуруз яки бодай игү. Сугарулы көтүлек.* □ *Сугарулы болыннарга мохтаҗлык зур.* Каз. утл.

3. Сугару (2 мәгъ.) юлы белән эшләнә торган, шуңа нигезләнгән (игенчелек һәм аның тармаклары турында). *Урта Азия — иң борынгы сугарулы игенчелек районнарының берсе.* Соц. Тат.

СУГУ *ф.* **1.** Кул белән яки берәр әйбер белән кискен бәрү. *Йодрык белән сугу. Атка чыбыркы белән сугу.* □ *Кадакны бер сугуда төбенә кадәр батыра аласыңмы?* Г. Әпсәләмов. *Их, әнә шулай көз көннәрендә эзләп табып, таяк белән сугып төшереп ашаган алманың тәмен белсәгез иде сез!* И. Гази. || *диал.* Кыйнау. *Шундый --- атны Кулың барып ничек сугасың?* М. Гафури.— *Кызганмыйча сук шул явызларны!* Т. Гыйззәт. || *диал.* Суктыру, җәза бирү. *Габделкаюм караганда, озын өстәлгә йөзтүбән --- яткырып, берәүне сугалар иде.* М. Гали.

2. Берәр нәрсәгә бәреп, яңгырау тавыш чыгару; кагу. *Төшке ашка чакырып чаң сугу.* □ *Барабан суккан, музыка уйнаган һәм җырлаган тавышлар ишетелә башлады.* Ш. Мөхәммәдев.

3. Вакытның күпме икәнен белдереп, тавыш чыгарып алу (сәгать һ. б. ш. турында). *Сәгатьнең берне сугуы.* □ *Кызыл мәйдан. Сугa курантлар. Безнең җирдә балкып таң туа.* Н. Дәүли.

4. Ашлыкның: башактагы, кузактагы бөртекләрен махсус кагып кою, чыгару, алу. *Игенне комбайн белән сугу. Элекке заманда ат белән борчак сугу. Су белән эшләүгә корылган сугу машинасы.*

5. Махсус калыпка салып ясау, эшләп чыгару (кирпечне һ. б.). *Акча сугу. Кирпеч сугарга өйрәнү.* □ — *Черепицаны үзебез суга алмыйбызмы?* Г. Бәширов. || *күч. сөйл.* Бик тиз һәм җиңел генә ясап, эшләп чыгару. *Приборлар төзүнең әлифбасын да юньләп белмәгән йөзләп эшче һәм бер-ике инженер беренче манометрларны эзерләп ничек куанганнар иде! Ә хәзер „Теплоконтроль" заводы көненә меңнәрчә приборны „сугып" кына тора.* Азат хатын.

6. *күч. сөйл.* Җиңел генә эшләп алу, табу. [*Фотограф:*] *Фотографның төшеме мин хыялланганча түгел. Казан тирәсендә минем коллегалар көненә илләшәрне сугалар.* Г. Мөхәммәтшин.

7. Махсус станда бөгеп ясау, эшләп чыгару (тәгәрмәчне һ. б.). *Тугым сугу.* □ *Сабиржан агай тәгәрмәч суга торган станга утырды да ашыкмый гына күн алъяпкычын салды.* М. Шәрифуллин.

8. Туку (киндерне, чыптаны һ. б.). *Палас сугу. Суккан сөлге. Киндер сугу.* □ *Җиремаз кешеләре кыш буе кап, чыпта сугалар, талдан кәрзин үрәләр.* Ә. Маликов.

9. Кагып һ. б. ш. рәвешчә беркетеп кую. *Ботинка үкчәсенә кадак сугу. Башмакка агач олтан сугу. Тырмага теш сугу.* □ — *Менә бит, төбен кыскач, кыршавын суккач, шап-шактый кисмәк булды.* Ф. Бурнаш. *Күпергә яңа өрлек сукканнар икән. Күпер астында шуның йомычкалары калган.* Х. Садрый.

10. Келәймә, пичәт һ. б. ш. нәрсәләрнең: билгесен төшерү, басу. *Агачка келәймә сугу. Штемпель сугу.* □ *Күпме вакыт үткәндер, без тракторчылар булып җиттек, кулларыбызга пичәт суккан язулар да алдык.* Н. Дәүли.

11. *сөйл.* Язып билгеләү, кәгазьгә һ. б. җирлеккә төшерү (цифрны, номер билгесен һ. б. ш.). *Хуҗалык кенәгәсенең битләренә номер сугып чыгу. Кайбер илләрдә акчага хайван сурәте сугу.* □ — *Дни!* — *дип, ул [малай] бераздан йөгереп кайтып керде.* — *Капкаларга акбур белән цифр сугып йөриләр!* И. Гази. *Командир ул язуны укып карады да, почмагына резолюция сугып, штабка җибәрде.* Ш. Маннур.

12. Канатларын шапылдатып кагу, җилпү (әре кошлар турында). [*Этәч*] *читән башына очып менде дә, канатларын шап-шап сугып, бугазын киереп кычкырды:* — *Кикрикүк!* И. Гази.

13. Гадәттәгедән көчлерәк тибү (йөрәк, пульс турында). *Аның йөрәгенең куәтле сугуы минем бөтен кулым өстендә тоела башлады.* Ф. Әмирхан. *Врачлар аның нәкъ баш түбәсенә плексигластан уч төбе кадәр ямау салдылар. --- Ямауның сәгать йөрүе төсле һәрвакыт тик-тик-тик итеп сугып торуын ишетә торган булып китте ул.* Каз. утл.

14. Ышкып-кырып, тәнне, тирене җәрәхәтләү (камыт һ. б. турында). *Атның муенын камыт сугу. Ыңгырчак сугу.* □ [*Ат караучы*] *барлык сбруйларны тикшереп чыкты. Камыт, ыңгырчак киезләренә бербер нәрсә булмаганмы, алар Турыкайның [атның] аркасын сугарлык түгелме...* А. Расих.

15. Үсемлекләрне, игеннәрне күпләп зарарлау (кырау, боз һ. б. турында). *Чәчәкләрне кырау сугу. Кар әз төшкән елны уҗымнарны салкын сугу.* □ — *Бөтен басуыбызны боз сукты.* Р. Ишморат.

16. Организмга зарарлы тәэсир итеп, чирләтү, имгәтү. *Яланбаш озак йөргәндә кояш сугу. Паралич сугу. Көчле тавышның башка сугуы. Авыр күтәрүнең билгә сугуы. Эссе сугу.*

17. Тиеп, бәреп, зарарлау (яшен турында). *Яшеннең агач башын сугуы.* □ *Яшен ул хайванны бик сугучан.* Г. Газиз.— *Күк күкрәгәндә урамда йөрергә ярамый, яшен сугар.* Н. Дәүли.

18. *күч.* Күңелгә, хисләргә бик авыр тәэсир итү. *Тәнкыйтьнең мин-минлеккә сугуы.* □ — *Моннан да ямьсез, күңел өшеткеч, психикага суга торган сүзнең булуы мөмкинме?* Ф. Хөсни. *Дүрт ел мәдрәсәдә укып, мин күпне белəм инде дип йөргән Габдулланың горурлыгына китереп сукты бу.* Ә. Фәйзи.

19. *гади с.* Хорафатка, дингә ышанучыларча, бәлаказа, бәхетсезлек, чир китерү (мифик көчләр һ. б. ш. турында). *Зәхмәт сугу.* □ *Лəгънәт кенә сукса иде сез кәһәр сукканнарны!* Ф. Әмирхан.— *Йөзе кара булсын! Бәддога суксын!.. Әле берегез шәригатькә каршы йөргән өчен йөзе кара булып җен сукты бит!* М. Гафури.

20. *күч.* Зарар ясау, бәхетсезлек-күңелсезлек, уңайсызлык китерү (төрле сәбәпләр, хәлләр-шартлар һ. б. турында). *Ашыгып эшләүнең сыйфатка сугуы. Килешсез эшнең авторитетка сугуы.* □ *Эшсезлек негрларга тагын да катырак суга.* Соц. Тат.

21. Җибәрү, бирү (телеграмманы).— *Кайтыр алдыннан телеграмма сук.* К. Нәҗми.

22. *күч. сөйл.* Төвәккәлләп сатып алу яки бүтәнчә килешеп, тиз генә үзеңнеке итү. *Кадерле товарны очрату белән үк сугып алу.* □ [*Бай — икенче бер сәүдәгәр турында:*] *Минем сәүдәмә аркылы төшеп йөдәттте бит инде. Тагын мин сәүдәләгән ябаганы сугып куйган бит.* Ш. Мөхәммәдев.— *Маһруй белән Гөлйөземне икебез икесен сугып алыйк та, Сөнгать белән Гатауны төпсез тагаракка утыртыйк.* М. Фәйзи.

23. *күч. сөйл.* Әңгәмә, гәп, сүз алып бару, оештыру. *Халыкның бер бүлеге, сәкегә кырын төшкән хәлдә, төрле баптан гәп сугарга тотындылар.* Г. Ибраһимов. *Агайлар, тәмәке көйрәтә-көйрәтә, шул көннәрнең вакыйгаларына бәйләп, Зөһрә йолдыз турында әңгәмә сугалар.* Г. Минский.

24. *күч.* Турыдан, бик кискен итеп яки, киресенчә, кинаяләп сөйләү, әйтү.— *Берәү дә гаепле түгел, ә буровойлар бораусыз! Шушымы инде җитәкчелек? — Әнә кая китереп сукты Мансур. Ә дөрес әйтә бит.* Г. Иделле.

25. *сөйл.* Уйнау (өстәл уеннарын һәм кайбер хәрәкәтле уеннарны). *Домино сугу. Карта сугу. Шар сугу.* □ *Кәшәкә сугучы малайлар* [*урамда уйный иде*]. А. Гыйләҗев. *Фойеда дүрт егет, авызларына папирос кабып, бильярд сугып ята.* Х. Сарьян.

26. *күч. сөйл.* Талымсызланып һәм бик җитез ашау (кеше турында). *Икмәк кисәкләрен --- тәмле итеп суга башладылар* [*малайлар*]. Ф. Кәрим. *Уттай эш өстендә бер ипине бер үзең сугардай булып кайтып керәсең.* Ш. Маннур. || Исерткеч эчемлекне: эчү (савытында беткәнче). *Получка алган көннәрдә ипташларе белән берәр яртыны алып кайтып сугалар иде* [*ямщиклар*]. М. Гали.

27. *күч. гади. с.* Урлау. *Ишек алдыннан көрәк, балта ише нәрсәләр югалгалады. Бигрәк тә Ләсел малайлары усал иде — суккалап йөриләр.* Э. Касыймов.

◇ **Сукса тимер өзәрлек (өзәрдәй)** — бик көчле, таза; типсә тимер өзәрлек.— *Акылы да җитенкерәми күрәсең, югыйсә кол булып йөрерлек малай түгел инде, сукса тимер өзәрлек егет.* М. Әмир.

СУГЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сугу (**1**, 2, 4—11, 14, 18, 21, 23, 25—27 мәгъ.).

2. Бәрелү, ник орынып китү. *Диңгез дулкыннары бер-бер артлы Текә ярга килеп сугылалар.* Э. Ерикәй.— *Башым бик ник сугылды* [*таудан тәгәрәгәндә*], *кулым сынган, ахрысы.* Ш. Камал.

3. Тайпылу, читкә омтылу, китү.— *Мин ары сугылып, бире сугылып Лотфулланың кулыннан ычкынырга омтылам.* Э. Айдар. *Кинәт әрәмәлектә шау-шу купты: атлар өркеп бер якка сугылдылар, кешеләр куркып кычкырып җибәрделәр.* А. Шамов. || Юнәлешне белдергән сүздән соң: шунда юнәлү, китү. *Башта без чокыр эчләп бара торган зур юл белән киттек һәм байтак барганнан соң гына юлдан сулга, агачлар арасына сугылдык.* С. Җәлил.

4. Юл уңаеннан гына керү, кереп чыгу.— *Озаклап утырырга вакыт юк, Хәйрулла абзый. Киңәшмәдән кайтып барышлый гына сугылдым.* Ф. Хөсни. *Нургали, беркая да сугылмыйча, туры сыерлар абзарына китте.* Э. Еники. || Берәүгә мөрәҗәгать итү, берәр нәрсә белешеп, сорап бару.— *Алай да син минем кызның йоласын беләсең микән? Ул үзенең теленә торырдай чичән егеткә генә чыгам дип ант иткән бит. Монда күпләр сугылып карады.* Н. Исәнбәт. *Көз җиткәч, мөгаллимнәр анда сугылып, монда сугылып урын әзләргә тотыналар.* Ш. Әхмәдиев.

СУГЫМ *и.* **1.** Иткә махсус суела торган йорт хайваны; итлек. *Сугымга мал ашату. Сугым сую.* □ [*Гыймран*] *урам буйлап китеп барды. Бер капкага керде, сугымга мал сорады, тагын берсенә керде, тагын сорады.* Г. Ахунов. || Ит өчен хайван сую эше. *Байгузиннар уникә каз, бер тана, бер илəмсез зур дуңгыз һәм, өч хуҗа берләшеп, бер яшь ат суйдылар. --- Бу — һәр көзен кабатлана торган сугым.* Ә. Еники.

2. *с. мәгъ.* Иткә сую өчен билгеләп, атап куелган. *Сугым сыер.*

СУГЫМЛЫК *и.* Суярга, сугымга дигән мал. *Гыймран агайның сугымлык сатып алуында мин безнең бригада егетләренең берсендә дә булмаган кәсепчелек һәм сәүдәгәрләр осталыгы күрдем.* Г. Ахунов.

СУГЫМЧЫ *и.* Сугым, мал суючы. *Сугымчы бер карауда сыерның үлчәвен әйтә ала.* Г. Гобәй.

СУГЫШ *и.* **1.** *к.* сугышу (2—4 мәгъ.). *Аулакта инде, билгеле, җырлашасың, арка сугыш, балдак салыш уйныйсың.* А. Шамов.

2. Бер-береңә сугу, кыйнаш. *Борчак җирендә бәрелешү — безнең* [*малайларның*] *арадагы сугышларның актыгы булды.* Г. Ибраһимов.

3. Дәүләтләр, армияләр һ. б. ш. арасындагы коралларны көрәш. *Ватан сугышы. Сугыш игълан итү. Сугыш коралы. Партизан сугышы. Гражданнар сугышы. Азатлык сугышы.* □ *Назимов сугыш уены өйрәнүче --- солдатларга шактый озак карап торды.* Г. Әпсәләмов. *Төзелеш дәвам итте Хәтта сугыш барганда.* М. Максуд. || Шул көрәшнең аерым бер бәрелеше. *Сугышка керү. Штык сугышы. Разведка сугышы. Һөҗүм сугышы.* □ *Башлап ул тылда, госпитальдә эшли. Аннары бер-ике сугышта була.* Г. Иделле. *Шәһәр тирәсендә сугышлар бара иде.* Ш. Усманов.

◇ **Сугыш алласы** — туп, пушка һ. б. ш. артиллерия коралы. *Сугышның алласы — туп!* Н. Исәнбәт. *Бер генә минутка да тынмыйча, „сугыш алласы" — артиллерия һәм миномётлар ата.* Г. Әпсәләмов. **Сугыш кыры (мәйданы)** — сугыш бара торган урын; фронт. *Үләр идем аклап йөрәгемнең Керсез антын сугыш кырында.* М. Җәлил. *Ачык сугыш мәйданында без аларны тар-мар итеп ташладык.* Ш. Камал. **Сугыш төтенен иснәү** — фронтта булу, сугышларда катнашу. *Мостафа һәм аның шикелле үк сугыш төтенен иснәп кайткан берничә солдат --- әшче дружинникларны Бакалтай таллыгында мылтык куллануга өйрәтәләр.* К. Нәҗми. **Сугыш уты** — сугыш куркынычы, сугыш. *Кемдә намус бар — Безнең белән бас Сугыш утына каршы.* Ә. Исхак. **Сугыш уты кабызу** — басып алу сугышы башлау. *Сугыш уты кабызырга ирек бирмәбез.* Җыр. **Сугыш уты кабызучы** — басып алу сугышын пропагандалаучы һәм шуны башлаучы; агрессор. *Яңа туган балаларның бишекләренә бомбалар ташларга хәзерләнүче фашистларга — сугыш уты кабызучыларга нинди көчле нәфрәт кабынмый да, нинди ярсу булмый?!* Г. Әпсәләмов. **Сугыш чукмары** — 1) сугышырга, ызгышырга гына торучы; күп сугышучы, ызгышучы. [*Илдарның*], *сугыш чукмары буларак, маңгаенда шеш бетеп тормаган.* Г. Гобәй; 2) сугыш уты кабызучы, агрессор. *Сугыш чукмарлары, акырынмагыз, Без бит курка торган ил түгел.* Ә. Ерикәй.

СУГЫШТАШ *и. сир.* Берәү белән фронтта, сугышта бергә булучы. *Сугышташлары аның иң якын туганнары булып чыгалар. Аның авыр кайгысын җиңеләйтү өчен бөтен чараларны күрәләр.* Г. Иделле.

СУГЫШТЫРУ *ф. Йөкл. юн. к.* сугышу (2—4 мәгъ.). || Кызыгы, мәзәге өчен талаштыру (кошларны, вак җанварларны). *Миңлебай унҗиде яшенә кадәр мәдрәсәдә укыса да, атага бер булганлык сәбәпле, иркә*

булып, укуга күп ихлас куймаенча, күгәрчен очыру, әтәч сугыштыру шикелле уеннар берлә мәшгуль булды. Ш. Мөхәммәдев.

СУГЫШУ *ф.* 1. *Уртак. юн. к.* сугу (1, 2, 4—5, 7—11, 21, 23, 25 мәгъ.).

2. Бер-береңә сугып, бәреп кыйнашу. *Безнең бабай тирәсендә үзара сугышу, бәйләнешү, бер-береңне кимсетү-хурлау кая инде ул!* Г. Гали. *Кикрикләрен кинга батырып сугышып торган ике әтәч, куркып, аның аяк астыннан икесе ике якка очты.* Г. Әпсәләмов. *Ул, сугышканда, үзе сукса да, үзенә суксалар да, әтәч шикелле сикереп-сикереп куя иде.* Г. Гобәй.

3. Корал белән көрәшү (дәүләтләр, армияләр, иҗтимагый сыйныфлар, сугышчылар турында). *Фронтларда сугышып йөрдем мин.* Б. Рәхмәт. *Кол булып яшәүгә караганда сугышып үлү артыграк.* А. Шамов. *Революция өчен сугышуларыбыз бушка китмәде.* Ш. Камал.

4. *күч.* Берәр нәрсәгә ирешү өчен бик нык тырышу, көрәшү. [*Кеше*] *никадәрле авырлыклар күрсә дә, сабыр итә, авырлыкларга каршы сугыша.* М. Гафури. *Сугыш елларында әрсезләнеп киткән әрем-билчәннәр, шайтан таяклары белән куллар канланганчы, тырнаклар купканчы сугыша-сугыша саклап калган, нинаять, бөртеклап, кадерләп җыйган тары бит ул.* А. Гыйләҗев.

СУГЫШЧАН *с.* 1. Сугышка, сугышуга мөнәсәбәтле. *Гаскәрләрнең сугышчан тәртибе.* □ *Аның кечкенә генә сугышчан гомерендә бер юлы гына сөйләп бетерә алмаслык вакыйгалар бар.* Н. Дәүли.— *Менә, бүген безнең алдыбызга кичектерелми үтәргә куелган аеруча мөһим сугышчан приказ шушы. Бу приказны үтәү өчен безгә өч кеше кирәк.* Ф. Кәрим.

2. Сугышка сәләтле, кыю һәм тәвәккәл. *Сугышчан армия.* □ *Алар аз санлы кешеләрдән сугышчан группалар төзегәннәр.* Г. Әпсәләмов. *Ассирия остасы үзләренең әсирләрендә һәрвакыт таза гәүдәле сугышчан ирләрне генә гәүдәләндерергә тырышканнар.* Г. Гали. || Сугышчанлыкны белдерә торган. *Сугышчан кыяфәт. Сугышчан рух.* □ *Сугышчан антын --- җиренә җиткерде ул.* С. Хәким.

3. Бик актуаль, агитацияләү көче зур булган (лозунг, мәкалә, речь һ. б. турында). *Сугышчан иҗат.* □ *Ул речен барыбыз өчен дә сугышчан лозунг булып әверелгән сүз белән тәмамлады.* К. Нәҗми. *Алгы сызыкта гына кирәкле геройларны күрергә, материал табарга, сугыш хәлләрен күзәтергә мөмкин. Шунсыз газетаны оператив һәм сугышчан итеп булмый.* М. Җәлил.

СУГЫШЧАНЛЫК *и.* Сугышчан кешегә, гаскәргә һ. б. хас сыйфатлар; сугышчан булу хәле. *Инспектор легионерларның сугышчанлык ягыннан бигрәк сәяси якларын [тикшерде].* Ш. Усманов. *Автор вакыйгалар үзәгендә булып, үзен шунда катнашучы итеп түгел, ә читтән күзәтеп, бөтенесен бик тәртипле теркәп баручы кебек тәэсир калдыра. Мондый алым очерклларның сугышчанлык сыйфатын киметә.* Г. Иделле.

СУГЫШЧЫ *и.* 1. Солдат, рядовой гаскәри. *Элемтәче сугышчылар.* □ *Каты сугышлардан соң капитан Фәтхетдинов тугыз сугышчысы белән --- дошман тылына бәреп керә.* С. Шакир.

2. Сугышта катнашучы, сугышучы. *Хәмит һәр сугышта үзен оста сугышчы, Ватанның батыр сугышчысы итеп таныты.* Р. Ишморат.

3. *с. мәгъ.* Сугышчан, сугышучан. *Алар бик сугышчы халык.* Г. Камал. *Авылда чакта зерә сугышчы малай идем,— диде ул елмаеп.— Безне сугышчы Аю Гатаулла малайлары диләр иде. Д хәзер мин җил иссә дә егылырга торам.* Г. Әпсәләмов.

СУД *и.* 1. Дәүләтнең гражданнар арасындагы низаг һәм җинаять эшләрен хәл итүче хөкем органы. *Совет суды. Халык суды. Суд тикшерүчесе. Суд башкаручысы. Хәрби суд.* □ *Милиция, инсесен дә [сугышучыларны] әлэктереп, эшләрен судка бирә. Суд штраф сала.* Ә. Айдар. || Коллективта җәмәгать тәртибен бозуга бәйле һ. б. ш. эшләрне хәл итү өчен, шул коллектив членнарыннан сайлап куелган җәмәгать органы. *Иптәшләр суды.* □ — *Мин сине барыбер ячейка судына бирәчәкмен.* Г. Ибраһимов. || *җыйм.* Суд утырышында катнашучы судьялар. *Залда һаман түземсезлек арта, ә суд дәшми.* З. Мансур. [*Судья:*] *Сораулар бетте, суд киңәшкә керә, ярты сәгатьтән хөкем карары игълан ителер.* М. Гали.— *Тыныч кына торыгыз, суд килә!* К. Нәҗми.

2. Суд органнарының эшне тикшерү утырышы. *Суд башлану.* □ *Судтагы бөтен халык түзә алмыйча яңгыратып кул чапты.* Г. Камал.— *Димәк, әле иптәшләр суды булачак.* А. Алиш. *Киләсе атнага безнең авылда Шәйхетдиновларга күргәзмә суд була.* Т. Гыйззәт.

◇ **Суд алдына (каршысына) басу** — гаепләнеп, суд җаваплылыгына тартылу.— *Карт башым белән суд алдына барып басмам, юк.* А. Шамов. **Суд эскәмиясенә утыру (элэгү)** — *к.* суд алдына басу. *Караклар суд эскәмиясенә элэккәннәр.* Соц. Тат. *Ул иртәгә суд эскәмиясенә утырачак.* Н. Фәттах. **Судка бирү (кую)** — суд хөкеменә тапшыру; рәсми рәвештә мөрәҗәгать итеп, судның тикшерүен һәм хөкем чыгаруын үтенү. *Крестьяннар, үзләрен хаклы санап, эшне судка биргәннәр.* И. Гази.— [*Хурлаган*] *өчен мин аның эшен судка куям.* Р. Ишморат.

СУДАК *и. зоол.* Төче суларда һәм диңгездә яши торган, алабугалар семьялыгыннан булган кыйммәтле балык. *Торпеда кебек җитез судакларын кармакка каптырып караган кеше Ык буйларын онута аламы?!* М. Шабаев.

СУДЛАШУ *ф.* Дауны-дәгъваны судка мөрәҗәгать итеп чишү; суд аркылы эш итү. *Сукрана әти. Д үзе ил-көн эчендә тавыш кубарып, судлашып йөрергә дә уңайсызлана.* Ш. Маннур. [*Рамай:*] *Сабир белән судлашып бер нәрсәсез калдым.* Т. Гыйззәт.

СУ'ДНО *и.* Пароход, кораб һ. б. ш. йөзмә корылма. *Кит аулау судносы. Суднолар төзү һәм ремонтлау заводы. Җилкәнле судно. Транспорт суднолары. Хәрби судно.*

СУ'ДНОЧЫ *и. махс.* Суднолар төзү, ремонтлау эшендә эшләүче. *Чистай судночылары.*

СУДЬЯ *и.* 1. Судка (1 мәгъ.) кергән эшләрне закон нигезендә хәл итеп хөкем чыгаручы хезмәткәр. *Халык судьясы. Судьялар коллегиясе.* □ *Укый судья суд карарын, Төбәлгән күзләр аңа.* Г. Хуҗи.

2. Спортта: ярыш кагыйдәләре һәм шартларының үтәлешен күзәтеп, шулай ук бәхәсләрне хәл итеп хөкем чыгару өчен билгеләнгән кеше. *Ярышның судьясын билгеләү. Баш судья.*

СУДЬЯЛЫК *и.* Судья белгечлеге, хезмәте һәм вазифасы. *Судьялыкка уку. Спорт ярышларында судьялык итү.*

СУЕЛУ *ф.* 1. *Кайт. юн. к.* сую (1 мәгъ.). Үз-үзенә кул салу, үзеңне сую.— *Гафият дөрес әйтә: җир шундый кирәк, хет суел.* И. Гази.

2. Кан чыгар дәрәҗәдә ышкылып кырылу, җәрәхәтләнү, чиләнү (тән турында). *Бәрелеп тез суелу. Үкчә суелу. Җилкә суелу.* □ *Таш-тауларда, калын баткак урманнарда йөреп, минем аякларым кабарды, суелды.* М. Максуд. [*Атның*] *муены, камыт тигәнлектән, чеп-чи, суелып беткән иде.* Ш. Мөхәммәдев.

СУЕР *и.* Көртлекләр семьялыгына керүче эре кош; *русчасы:* глухарь.

СУЕШ *и.* Күпләп үтереш (суеп, чәнчеп үтерү турында). *Анда яман сугыш, куркыныч!.. Туплар атып, күкләр калтыратып, Анда үтереш, суеш, бетереш.* М. Җәлил. *Халыкның көчләрен таркату өчен, патша властьлары милләтләр арасында дошманлык уты кабыздылар, канлы еврей погромнары, азербайҗаннар белән әрмәннәр арасында суешлар оештырдылар.* КПСС тарихы.

СУЗАН *с.* **1.** Озын, чандыр гәүдәле. *Сузан кеше. Сузан малай.* □ *Ул буйлы булса да, кайбер кинәт үсеп киткән кызлар кебек котсыз сузан, юка кыз түгел иде.* А. Гыйләҗев.

2. Гадәттәгедән озынрак һәм килешсезрәк (гәүдә, муен һ. б. турында). *Судья — сузан буйлы, чандыр, кыяфәтсез карт.* А. Әхмәт. *Сузан муенларын әрлебирле йөрткән гигант краннарга күптән инде игътибар иткән идем.* А. Расих.

СУЗАНЛАНУ *ф.* Сузанга әйләнү.

СУЗАЮ *ф. диал.* Озынаю. *Нигә бик озын булып үскән дисеңме? Анда бит, туганкаем, бездәге төсле кояш юк. Шәмдәлләр дә шәмдәлләр! Өстәвенә сәхнә арты тулган бау — берсен тартасың, берсен кимәтәсең, сузыласы да сузыласы! Кеше менә шуннан сузаеп, озын булып кала да инде!* Г. Ахунов.

◇ **Сузаеп тору** — 1) кирәксез яки тиешсез урында туп-туры басып тору. *Кеше эшләгән җирдә сузаеп тору;* 2) биек булып калкып, тирә-юньнән нык күтәрелеп тору. *Габитов таныш урманнарга, кызыл маңгайлы таныш тауларга, сузаеп басып торган буровойларга карап кайтты.* И. Гази.

СУЗУ *ф.* **1.** Тарту, киерү һ. б. юл белән озынайту. *Резинны сузу.* □ *Бик каты сузсаң, җеп тә өзелә бит: без дә чыдамадык.* Г. Ибраһимов.

2. Туры, төз рәвешкә китерү. *Аякны сузып утыру.* □ *Купшы офицер күкрәген киереп, кулларын бот буена сузып, кызу-кызу гына нидер әйтте.* Ә. Еники.

3. Кулны, гәүдәнең берәр өлешен яки кулдагы берәр нәрсәне: читкә таба юнәлтү, турайтып тоту. *Кулларны як-якка сузу. Чәнечкене иткә дип сузу.* □ *Хәлим тиз генә мунча ишеге төбенә килде. Колагын бәрәңге бакчасы ягына сузып тыңлап торды да шунда мунча өйалдына керде.* Г. Гобәй. *Брезент куртка-чалбарлар кигән пожарниклар машинадан төшеп чаштыр-чыштыр кайнаша башладылар, халыкны куып, әчәге сузарга тотындылар.* Ә. Еники. [*Сыер*] *озын муенын артка таба сузган да теле белән бозавын ялый, иркәли.* Каз. утл. || Алга таба җибәрү, алга чыгару, юнәлтү (башны, борынны, муенны). *Озын муеннарын сузып, саф-саф булып тезелешеп казлар кайтып киләләр.* А. Әхмәт.

4. Кулдагы нәрсәне берәүгә тәкъдим итеп, аңа юнәлтү; бирү. *Зәйнәп тиз генә кулындагы төргәкне Газизгә суза да үзе чыгып китмәкче була.* Ф. Әмирхан. *Кыз Сәфәргә сөлгене сузды һәм елмаеп нәрсәдер әйтте.* Ә. Фәйзи. *Кайсы коча, кайсы кулны кыса, Чәчәк суза кайсы кулыма.* Ә. Исхак.

5. Берәр юнәлештә урнаштыру, үткәрү, төзү, кору (юлны, телефон чыбыгын, кабельне һ. б. ш.). *Фронтта элемтәчеләрнең сазлык аркылы телефон сузуы. Шәһәрнең яңа районына трамвай юлы сузу.* □ *Станцадан төзелеш мәйданына дамба сузарга кирәк. Төзелешкә кирәкле барлык җиһаз шуннан киләчәк. Соңыннан тимер юл тармагы сузарбыз.* Г. Ахунов. *Үрмәкүчләр ботактан ботакка җеп сузган, пәрәвез корган.* Ш. Бикчурин.

6. Юнәлтү (өметне, күңелне һ. б. ш.). [*Мөнҗия Фәгыйләгә:*] *Сиңа Җантәһир өметен сузып йөри иде бит. Хәзер ничек соң, сүз салмыймы?* Ә. Камал. — *Минем өлешемә нәфсеңне сузма.* Т. Гыйззәт. *Алга, якты, маяклы юлга таба күңелләрен суздылар* [*ирек өчен көрәшүчеләр*]. Г. Ибраһимов.

7. Үтәлү-эшләнү яки тәмамлану вакытын кичектерү, озакка җибәрү; тоткарлау.— *Кем чәчүне җәй уртасына тикле суза?* Г. Бәширов. *Буржуа өчен сугышны сузу файдалы.* Ш. Камал.— *Юкка сузасың. Барыбер кайчан да булса бер әйтергә кирәк булачак.* Р. Ишморат. || Тиешеннән озаграк сөйләү. *Докладны бик сузу.*

8. Озайтып, озаграк дәвам иттереп әйтү (авазларны, сүзләрне).— *Да-а...— диде Гаяз, озак итеп сузып әйтте.* М. Әмир.— *Ах, мал-лай,— дип сузды Мәрданша бабай.— Нигә мине уятмадың соң син шул чакта?..* Г. Гобәй.

9. *күч.* Җырлау (гадәттә озын көйгә). *Озын-озын көйне кайгы-хәсрәт белән әкрен генә, әкрен генә суза башлыйбыз.* Г. Ибраһимов. [*Солдат*] *авыз эченнән әллә нинди бер көй суза.* Ш. Усманов.

10. *күч.* Тынлы уен коралларын уйнау турында. *Ул аккордеонын алып уйнап җибәрде. Чынлап та шәп суза икән гармунны!* М. Хөсәен. *Ул гармун остасы түгел, гадәти генә уйный; --- берәр моңлырак авыл көен сайлый да шуны хәсрәтле генә итеп сузарга тотына.* Ш. Маннур.

СУЗЫК *с. лингв.* Авыз куышлыгыннан һаваның тоткарлыксыз үтүе вакытында барлыкка килә торган (сөйләм авазлары турында). *Сузык аваз.*

СУЗЫЛМА *с.* Сузыла (1 мәгъ.) торган, сузылу үзлеге булган. *Резина кебек сузылма әйберләр.*

СУЗЫЛМАЛАНУ *ф.* Сузылмага әйләнү, сузыла торган булу.

СУЗЫЛМАЛЫ *с. к.* сузылма.

СУЗЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сузу (1—7 мәгъ.).

2. Буй юнәлештә урнашкан булу; озын булып күренеп тору. *Киң басулар сузыла еракларга, Як-ягына җитми карашың.* С. Урайский. *Басулар кардан арчылган, тик урманнан авылга таба сузылган тирән елга кары гына кояшка каршы күзне камаштырып ялтырап ята.* Г. Бәширов. *Алар заводка таба сузылган такыр юлдан берничә секунд сүзсез бардылар.* Г. Минский.

3. Билгеле бер вакыт дәвам итү. *Бер сәгатькә сузылган докладны бик зур дикъкать белән тыңладылар.* М. Гали. *Яңгыр озакка сузылмады.* Э. Касыймов.

4. Гәүдәне сузып, яту. *Ялчылар --- арганнар иде. Аш өенең сәндерәсенә сузылу белән үк үлек кебек йоклап киттеләр.* Г. Ибраһимов. *Тынып торганнан соң башын селкеп куйды* [*кәҗә*]. *Ләкин ул бик хәлсез иде, шунда ук авыраеп тагы идәнгә сузылды.* А. Расих.

5. Гәүдәне яки кул-аякны сузып үренү; тотарга, алырга омтылу. *Койма аркылы сузылып урамга карау.* □ *Фәлсәфәдән арган минутларында Муса мандолинага сузыла иде.* М. Максуд. *Айгыр, хуҗа кергәнне сизгәч, әкрен генә кешнәп җибәреп, Маликның кулына сузылды.* И. Гази.

6. Гәүдәне киереп, турайту.— *Атлар солыларын бетергәч, мине уятырсың...— ди* [*Фәйзулла*] *вә озын гына киерелеп сузыла да тиз хырылдап йокыга китә.* Ш. Камал. *Сукыр тычкан, рәхәтләнгәнлектән вә җылынганлыктан, тәмле-тәмле генә киерелергә, сузылырга тотынды.* Г. Тукай.

СУЗЫНКЫ *с.* Озаграк дәвам итә, озаккарак сузыла торган (тавыш, аваз турында). *Сузынкы гудок авазы.* □ *Хәтерләре калган кызлар сузынкы тавыш белән көйләп, шаулашып алдылар:— Чистартабыз ла инде, Нургали абый!* Ә. Еники. || Гадәттәгедән озынрак (башкарыла торган һ. б. төр әсәрләр турында). [*Дәрнең*] *ялыктыргыч озын, сузынкы булуын да әйтергә*

кирәк. М. Җәлил. *Элекке татар халык көйләре моңлы, сузынкы, төшенке, аһ-зар белән сугарылган булганнар.* Соц. Тат.

СУЙДЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* сую.

2. Кан күренер дәрәҗәдә ышкытып кырдыру, җәрәхәтләү, чиләндерү (тәнне). *Үкчәне суйдыру. Егылып тезне суйдыру.*

СУЙЛАК *с. диал.* Ялкау, иренчәк.

СУЙЛАКЛАНУ *ф. диал.* 1. Суйлакка әйләнү.

2. Ялкаулану; иренү. *Кече якта чаж да чож нидер пешерәләр, исе борынны кытыклый... Торырга бик вакыт! Тик кузгала алмый Гәрәй, суйлакланып ята.* А. Гыйләҗев.

СУКА *и.* 1. Авыл хуҗалыгында: иң гади җир сөрү коралы. *Сука тимере. Агач сука. Сука калагы.* □ *Кояш күтәрелә башлаган, --- ирләр сабаннарын, сукаларын шалтыратып кырга китәләр.* М. Гали. *Елдан-ел заманалар үзгәрәләр, Сука, тырма барысы артка калып бара.* М. Крыймов.

2. Җир сөрү-сукалау эше. *Сука өсте. Сукага билгеләнгән атларны ял иттереп алу. Сукага иртәнрәк торып чыгу. Язгы суканы иртәрәк башлап тизрәк тоту. Сукадан бушаганнарны бүтән эшкә күчерү. Хәзер суканың бөтенләй тракторчыларга гына кала баруы.* □ *— Кызу эш өсте, атлар буш түгел: кайсы урманда, кайсы сукада.* Т. Гыйззәт.

◇ **Сука сукалау** — 1) гадәттә бүтән төр авыл хуҗалыгы эшләре рәтеннән санап киткәндә кулланыла: сукалау, җир сөрү. *Сука сукалау, печән чабу кебек эшләрнең күптән механикалаштырылган булуы. Кырга сука сукаларга чыгу.* □ *— Мин булмагач, аларның сукаларын кем сукалар?* Г. Әпсәләмов; 2) иген игеп, крестьян булып гомер итү; гади крестьян булу.— *Без бит мужик! Безнең бабай сука сукалап үскән.* Г. Камал. **Сука тоту** — сука белән җир сөрү; сукачы булып гомер итү, иген игеп яшәү. *Аның җәй буе урак урып, сука тотып биле авыртмаган.* А. Шамов.

СУКАЛАУ *ф.* 1. Сабан-сука белән эшкәртү, сөрү. *Ат яки үгез белән сукалау. Вак, шәхси бакчаларны да трактор белән генә сукалау. Болынны сукалап культуралы көтүлек ясау.* □ [*Җир*] *юеш әле, икенче көнсез сукаларга ярамый.* М. Гали.

2. *күч.* Әзме-күпме канәгатьләнерлек сөйләшә белү, сөйләшү. *Яңарак кына теле ачылып, сукалый гына башлаган бала.* □ *Байтирәк халкының күбесе русча һәм чувашча шактый кыю сукалый.* Г. Бәширов. || *сөйл.* Сөйләшү, сөйләү, әйтү. [*Азат:*] *Моны ашаса, сыерның сөте шифалы, тәмле исле була.* [*Мәхмүт:*] *Дөрес сукалыйсың. Болай булгач, сиңа көтүне ышанырга ярый.* Ә. Камал. || Әзме-күпме канәгатьләнерлек укый-яза белү; хәреф тану.— *Кайбер газетларның хәрефләре бер дә ачык төшми. Безнең кебек яңа сукалый башлаган кешеләргә бик кыен.* М. Гафури. *Сукалый торгач бу чыннан Бер язуны укый бит.* Н. Исәнбәт. || Уен коралын: әзме-күпме канәгатьләнерлек уйный белү, башкару. [*Нургата — гитара уйнаучы кызга:*] *Болай ярыйсы гына сукалыйсың үзе.* Х. Вахит.

СУКАЧЫ *и.* 1. Сукалауда, җир сөрүдә эшләүче. *Ул сукачыны күрә дә: „Җир боза бит!" дип куя.* Г. Тукай.

2. *күч.* Гади крестьян, игенче.— *Бел, мирза, мин — туганнан бирле сахра куенында тирбәлгән бер сукачы.* М. Фәйзи.

СУКАЧЫЛЫК *и.* Сукачы һөнәре һәм кәсебе.

СУКБАЙ *и.* 1. Билгеле бер эше, кәсебе булмыйча, урыннан урынга күчеп, ил гизеп йөрүче ярым хәерче. [*Юлчының*] *өс-баш килеше һәр җирдә еш очрый торган сыранып йөрүче сукбайлар төркеменнән икәнлеген әйтеп тора иде.* Ш. Камал. *Сукбай кебек япа-ялгызың читтә йөрмәссең инде.* А. Гыйләҗев.

2. *с. мәгъ.* Сукбайга (1 мәгъ.) әйләнгән, сукбайлык тормышына күчкән. *Сукбай көнлекче. Сукбай юлчы.*

3. *с. мәгъ. күч.* Тәрбиячесез, караучысыз булып, теләсә кайда йөри торган. *Гражданнар сугышы елларындагы сукбай малайлар.* || Йорттан бизү яки хуҗасыз булу сәбәпле урам тормышына күчкән (эт турында).— *Дй, Җамай, күр әле: бер сукбай эт сине күзәтә.* Р. Батуллин.

СУКБАЙЛАНУ *ф.* Сукбайга (3 мәгъ.) әйләнү яки сукбай булып кылану. *Аның ире* [*нефть разведкасында эшләүче*] *җитәрлек сукбайланган иде, аны --- семья белән яшәргә өйрәтәсе бар иде.* Ш. Бикчурин.

СУКБАЙЛЫК *и.* Сукбай тормышы, шуның хәле. *Кая гына ләкин китсәк тә без, Сукбайлыкка яшьли салышып, Шул юллардан кире алып кайта Туган йортка йөрәк сагышы.* М. Җәлил.

СУККАЛАНУ *ф. к.* бәргәләнү. *Ул көне буе йөдәп чыкты. Башын кая куярга белми, бер ята, бер утыра һәм һаман суккалана иде.* Ш. Камал. *Шундый хәсрәтле чакларында да Маһруй апа кайгырса, башкаларга күрсәтмичә, эчтән генә кайгырды; еласа, бәргәләнми, суккаланмый, тын гына, бер үзе генә елады.* Г. Әпсәләмов.

СУККЫЧ *и.* Ашлык сугу машинасы. *Атлы суккыч.* □ *Күчәрбай чынлап та, үзе укый-яза белмәсә дә, ургыч, суккыч шикелле авыл хуҗалыгы машиналарында эшли белә торган алтын куллы егет иде.* М. Әмир. *Бусы кирәк иртә таңга Печән җыярга; Вакыт җитте суккычны да Карап куярга.* М. Сөндекле.

СУКМАК *и.* Кешеләр, хайваннар йөрүдән тапталып ясалган тар гына юл. *Урман сукмагы. Тау сукмагы. Сукмак салу. Кыр сукмагы.* □ *Таллык арасындагы сукмаклардан сылу кызлар су ташыйлар.* К. Нәҗми. *Чыклы сукмак, көмеш тамчыларда Калган төсле синең эзләрең.* З. Мәҗитов.

СУКНО *и.* 1. Йомшак шома өсле тыгыз тукыма (йоннан яки йон кушып тукыла). *Сукно фабрикасы. Солдат сукносыннан тегелгән куртка.* □ *Яшел сукно ябылган озын өстәлнең янында --- подполковник белән аның ике ягында яшьрәк ике офицер утырып торалар иде.* М. Гали.

2. *с. мәгъ.* Шундый тукымадан тегелгән. *Аның башында мескен бүрек, өстендә сукно казаки, аягында ялтыравыклы читек-кәвеш иде.* Ш. Камал. *Мәгъсүм үзенең сукно чалбарын яшел галифега алмашты.* Г. Гобәй.

СУКРАНУ *ф.* Берәүне тиргәп яки зарланып үз алдына сөйләнү. *Абзар буйларын каплап киткән кар эчендә, үз алдына кычкырып, сукранып, Нурый карт йөри.* Г. Ибраһимов. *Безнең әни кирәк булса да, булмаса да сукранырга ярата инде.* Ә. Фәйзи.

СУКТЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* сугу (1—5, 7—11, 14—16, 21, 23, 25—27 мәгъ.).

2. Машина яки ат белән сугу (ашлыкны). *Кырда ат белән борчак суктыру. Игенне комбайн белән генә суктырып бетерү.* □ *Атлы суккычта тары суктырдык.* А. Гыйләҗев.

3. Кыйнатып, җәза бирү. *Чыбык белән суктыру.* □ *Менә бу имән баганага сөрген атларын бәйләгәннәр, каторжаннарны да шуңа бәйләп суктыра торган булганнар.* Ә. Маликов. *Кәрәм абзыйны камчы белән суктырдылар. --- Аркасында жандармнарның камчысы биегәндә, аның күз алдында мәрхүм карт шахтер басып торды.* Г. Әпсәләмов.

4. *күч.* Читләтеп сөйләү, кинаяләү турында. *Читләтеп суктыру.* □ *Син нәрсә, һаман миңа• шул турыда суктырып сөйлисең.* Т. Гыйззәт.

5. *күч. сөйл.* Талымсызланып ашау. *Ипшне дә матур гына суктыра ул.* З. Мансур.

СУКЫР *с.* 1. Күрү тойгысыннан мәхрүм, күрә алмый торган.— *Сукырга суд юк.* М. Фәйзи. || *хурл.* Начар күрүче яки кылый күзле. *Аңа каршы берничә кеше көлешеп:— днә, Наратлык аермасына җитеп киләләр ич! Сукыр, кая карыйсың соң син!— диештеләр.* М. Гали.

2. *күч.* Әйләнә-тирәдәге эшләрне күрмәүче, хәлне белмәүче, бик игътибарсыз. *Гашыйк кеше — сукыр кеше диләр ич.* И. Гази.— *Сукыр булганмын икән, куенымда зәһәрле елан асраганмын, --- һәр нәрсәгә артык ышанып карый торган булганмын икән.* Ә. Камал. || Надан. *Әшче халкы — алар аңсыз, алар сукыр... Диделәр чит дошманнар безгә карап.* М. Гафури. *Безнең заманда техникадан сукыр кеше — бөтенләй сукыр кеше ул.* Г. Мөхәммәтшин. *Күчәрбай укый-яза беләме? — диде Гаяз, белмәгән булып.— Дөм сукыр.* М. Әмир.

3. Кеше ихтыярында булмаган, очраклыкка нигезләнгән, стихияле (табигать көчләре һ. б.). *Табигатьнең сукыр көчләре.* □ *Фән белән яктыртылмаган практика — сукыр практика ул.* Р. Ишморат. || Аныклы нигезе, эзме-күпме әһәмиятле сәбәбе булмаган, акылга нигезләнмәгән. *Капма-каршы хисләр утында яна ул: тирән шомлану йөрәген биләп ала, сукыр көнчелек акылын томалый.* Ә. Еники.— *Адәм, син берәүгә дә сукыр килеш ышанма.* Г. Коләхметов.— *Андый сукыр дисциплина буламы?* Г. Ибраһимов.

4. Томалап, кадаклап куелган (тәрәзә һ. б. турында). [*Авылның*] *башта мәчет манараларын, аннары ике катлы берничә йорты, иң ахырда сукыр тәрәзәле, „сәҗдәгә китмә" тәбәнәк өйләре күренде.* И. Туктар. *Тактадан корыштырган нәни куыш. --- Бер тәрәзә, ул да булса ярым сукыр.* И. Рәмиев.

5. Бозык, кортлы, төшсез (чикләвек һ. б. җимеш турында). *Сукыр чикләвек.*

6. Күзсез, ватык (инә һ. б. ш. турында). *Колхозның сукыр инәсенә кадәр кай җирдә ятканын күңелдән белә торган кешебез — завхозыбыз.* Т. Гыйззәт. || Тишелгән, бозылган (металл акча һ. б. ш. турында). *Сукыр акча. Сукыр тәңкә.*

◇ **Сукыр бәхет** — очраклы рәвештә ирешелгән бәхет, уңышлык. *Менә кая ул сукыр бәхет! Сине артиллериядән дөмбәслиләр, ә син исән! Могҗиза бит!* Г. Бәширов. **Сукыр да күрерлек** — теләсә кем күрерлек, ачык күренеп-беленеп тора торган. *Сукыр да күрерлек фактлар.* **Сукыр кычыткан** *бот.*— вак-вак ак чәчәкле, кычыткаңныкы сыман, ләкин чакмый торган яфраклы чүп үлән; *русчасы:* глухая крапива. **Сукыр лампа** — яктыны бик әз бирә торган, куыксыз керосин лампасы. *Мунчага сукыр лампа кую.* **Сукыр тавык** *хурл.*— 1) бик начар күрүче яки бик игътибарсыз кеше турында; 2) надан, аңгыра кеше турында.— *Надан халык — сукыр тавык.* Г. Гобәй. **Сукыр тычкан** *зоол.*— алгы аяклары җир казу өчен җайлашкан, бөҗәк ашаучы җир асты җәнлеге, имезүче хайван; *русчасы:* крот. **Сукыр тәкәле уйнау** *гади с. к.* күз бәйләш уйнау. *Яшьләрнең аулак өйдә сукыр тәкәле уйнавы.* □ *Тукта әле, Әпипә,— диде* [*Айсылу*]. *— Без синең белән сукыр тәкә уйнамыйк әле, яме?! Нинди өй ул тагын? Солтан йортыннан үз өлешеңне алып, аны туздырып, бөтенләй аерылып киттең бит?* Г. Бәширов. **Сукыр ут** *к.* скыр лампа. *Өйалдында сукыр ут кына, шулай да күрәм.* Ф. Хөсни. **Сукыр чебен (черки)** — 1) пар канатлы вак бөҗәк; күпләп, мыжгып оча торган әердәге черки. *Биредә һичбер борчучы юк. Очмый хәтта сукыр чебен дә.* З. Мансур; 2) *күч.* әрсез, һаман-һаман борчып торучы бәйләнчек кеше турында. [*Сәли:*] *Сез аучы! Менә шәп! Мине дә алып барсагыз иде бер?* [*Кәли:*] *Фу, сукыр черки икәнсез.* Каз. утл.

СУКЫРАЮ *ф.* 1. Сукырга әйләнү, күрми башлау. *Таза, мәһабәт вә матур бер карт биш ел эчендә йөз еллык картайган, сукырайган!* Ф. Әмирхан. *Зөләйханың күзләре сукырайган.* М. Гафури.

2. *күч.* Бик игътибарсызга әйләнү, тормышны, хәлләрне аңламас хәлгә төшү. *Политик яктан сукыраю.* □ *Гашыйк кеше ул тәмам сукырая.* М. Максуд. *Район оешмаларының күлы җитми. Үз мәнфәгатьләре белән сукырайган бер төркем кешеләр табигатьне талауларын сизми калалар.* А. Гыйләҗев.

СУКЫРЛАНУ *ф. к.* сукраю. *Вә ләкин ул күңелнең сахибы күрми сукырланса, --- Күңелдән тар бер әйберне табып булмыйдыр ул чакта.* М. Гафури.

СУКЫРЛЫК *и.* Сукыр булу хәле. *Мин боларның тупаслыгына, аяз көндә кояшны күрә алмауга ошашлы сукырлыкларына хәйран калам.* Г. Ибраһимов.

СУЛ *с.* 1. Гәүдәнең йөрәк ягындагы. *Сул күл. Сул күз. Сул аяк. Сул колак.* || Сул күл ягындагы. *Сул тараф. Сул якка борылу. Сул күзлек ватылу.* || Сул кулдыкы яки сул аякныкы (кул-аяк киеме турында). *Сул бияләйнең озаккарак чыдавы.* || Яр турында: агым юнәлешенә (түбәнгә таба карап) йөз белән торганда сул күл ягында булган. *Каманың сул ярына урнашкан Чаллы, Чистай шәһәрләре.*

2. Аскы, эчке, тыштан караганда күренми торган яки күренмәячәк (киемнең һәм киемлекнең, материалның ягы турында). *Ситсының сул ягы. Кабаланып, ялгыш майканың сул ягын әйләндереп кию.*

3. *кит.* Политик яктан кыюрак, кискенрәк һәм алдынгырак карашны яклаучы. *Сул көчләр. Сулрак рухлы шигырь. Эшчеләр хәрәкәтендәге сул һәм уң агымнар. Сул фикерле журнал.* □ [*Хөсәен:*] *Легаль, ләкин бик сул, дөресен генә әйткәндә прогрессив идеяләрне пропагандаларга тиеш булган газета чыгарырга җыенабыз.* А. Расих. || Тыштан сул күренеп, асылда уңнарны яклаучы (оппортунистик партияләр, эшлеклеләр һ. б. турында).

◇ **Сул ягы белән торган** — кәефсез, ачулы, үпкәле.— *Җаббар абзый, син бүген сул ягың белән торгансың ахры: һәрбер сүзгә тискәре барасың.* Г. Ибраһимов. **Сулга эшләү** *ирон.*— дәүләт яки коллектив җиһазыннан-коралыннан, эш урыныннан файдаланып, эшләүченең интересын күздә тоткан эшләр башкару. *Алар — юк-бар бер сум хакына сулга эшләргә омтылучы кешеләр дигән фикер туган* [*кайбер шоферлар турында*]. Соц. **Тат.**

СУЛАГАЙ *с.* 1. Сул (кул турында). *Сулагай кул белән язарга өйрәну.* □ *Ул сулагай куллап чыбыркыны әйләндерә-әйләндерә туры кашка атны ныклап каезлый башлады.* Ш. Камал.

2. Сул кулы яхшырак эшли торган яки сул кулы белән генә эшләүче (кеше турында). *Сулагай кеше. Сулагай уракчы.* □ *Уң кулы протезлы булганга, ул сулы белән яза иде. Аңа укучылар „сулагай абый" дип кушамат та кушып өлгергәннәр иде инде.* К. Латыйпов.

3. *күч. ирон.* Дәүләт яки коллектив җиһазыннан-коралыннан, эш урыныннан файдаланып эшләнә, ләкин табышы-файдасы эшләүченең үзенә була торган һ. б. ш. (эш, кәсеп турында). *Сулагай рейс.* □ *Ул кайбер „сулагай" эшләрне киявеннән яшереп тә калдырды.* Ә. Еники.

4. *рәв. мәгъ.* Сул кул белән. *Сулагай эшләү.* □ *Сәлимә сулагай ура икән.* Г. Бәширов.

СУЛАГАЙЛАП *рәв.* Сул күл белән. *Сулагайлап рәсем ясау. Сулагайлап сугу.*

СУЛАГАЙЛЫК *и.* Сулагай (2 мәгъ.) булу сыйфаты. [*Гармунны оста уйнамавымны*] *мин үземнең сулагайлыктан күрәм.* Ш. Маннур.

СУЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сулау I. || Чылану, юешләнү; дымлану. *Яңгырга әләккәндә кием сулану.* □ *Кулында аның суланган мимоза букетлары.* М. Җәлил. *Баржа иске. Урынында торганда да трюмы суланып тора.* Ш. Усманов. *Суланып бүрткән рамнарны ике куллап этә торгач тәрәзәне ачып җибәрдем.* А. Гыйләҗев.

2. Сүл суы тулу яки юешләнү (кабарган җир, җәрәхәт һ. б. ш. турында). *Янгында кызарган тән, урыны-урыны белән кабарып, сулана башлады.* Ә. Маликов.

СУЛАУ I *ф.* Су белән чылату, юешләү. *Көлтә бавын сулау. Чалбарны сулый-сулый үтүкләү.* □ *Ул кара такта янына килде, чүпрәген сулады да тактаны сөртә башлады.* Г. Гобәй.— *Сохарилары күгәрә төшсә дә, суласаң шома үтә икән.* И. Туктар.

СУЛАУ II *ф.* **1.** Организм эченә, башлыча үпкәгә һава алу һәм чыгару. *Үпкә белән сулау. Тире күзәнәкләренең сулавы. Саңак белән сулау. Үсемлекләрнең сулавы. Хайваннарның эсседә еш-еш сулавы.* □ *Игеннәр сулый, күтәрелә.* Соц. Тат. || Берәр нәрсәгә яки кешегә: сулышны җибәрү, юнәлтү. *Тәрәзәгә сулап тору. Тыгын автобуста барганда берәүнең муенына яки аркасына сулау.*

2. Сулыш белән эчкә алу, суыру. *Арыш исен сулап икәү бергә Йөргән кебек булдым басуда.* Н. Баян. *Күкрәгемне киереп, кышкы төннең Туялмыйча сулыйм һавасын.* Һ. Такташ.

СУЛКЫЛДАУ *ф.* **1.** Кан йөреше, йөрәк тибеше тәэсирендә авыртып-авыртып, өзек-өзек сызлап тору (авырткан һ. б. ш. җир турында). *Җәрәхәт сулкылдау. Ис тигәндә чигә сулкылдау. Теш сызлаганда яңак сулкылдау.* □ *Аның йөрәге ашкынып типте, чигә тамырлары сулкылдады.* Каз. утл. *Ящиклар күтәреп сулкылдаган беләкләр язылганчы, Ильяс сабыр гына көтеп утырды.* Р. Төхфәтуллин.

2. Елаган, күңел тулган һ. б. вакытта: кискен һәм өзек-өзек сулыш алу; үксү. [*Елаучы балаларның*] *тавышлары басылды басылуын, тик күзләреннән яшь агу туктамады һәм сулкылдаудан иңбашлары сикереп-сикереп ала иде.* Л. Ихсанова. *Әйләнә-тирәдә салам кыштырдап ала, авыр сулаган, сулкылдап куйган тавышлар ишетелә.* Г. Бәширов.

СУЛЛАП *рәв. сөйл.* Сул күл яки як белән. *Суллап әшләү.*

СУЛЛАШУ *ф.* Сулга (3 мәгъ.) әйләнү, сул булып китү. *Буржуаз партияләрнең яки политик эшлекләрнең суллашуы. Парламентның суллашуы.* □ *Сәяси яктан ул хәзер шактый суллашты, кызылланды.* С. Җәлил. [*Италиядә*] *муниципаль сайлаулар илдә дәвам итә торган суллашу тенденциясен раслады-лар. Сул партияләр, бигрәк тә коммунистлар партиясе, яңадан җиңүгә ирештеләр.* Соц. Тат.

СУЛЛЫК *и.* Сул (3 мәгъ.) булу хәле. *Суллык авыруы. Политик суллык.*

СУЛУ I *ф.* **1.** Шинә башлау яки шинү (үсемлек турында). *Белем гөле — сулмас гөл.* Н. Исәнбәт. *Бакчада сулды чәчәкләр, Төшкәч көзге кыраулар.* Ә. Исхак. || Көеп, төссезләнә башлау яки төссезләнү, сафлыгын югалту (табигать турында). *Көзгә таба болыннарның сула башлавы.* □ *Яңгыр үткәч тагын җанланалар Сулган гөлләр, сулган далалар.* Ә. Ерикәй.

2. Ябыгып төссезләнү, ямьсезләнү (бит, йөз һ. б. ш. турында). *Нинди сөйкемле алсу йөзе дәррәү сулып китте Гөлсем апаның.* Г. Гобәй. *Ул шушы берничә ай эчендә бик нык таушалган, күз төпләре капчык-лана башлаган, битләре дә, иреннәре дә сулган.* Г. Бәширов. || Ябыгып, боегып, ямьсезләнеп калу. [*Гөлҗиһан*], *кайчандыр таза һәм чибәр генә булып, хәзер инде сулган һәм күләгә генә булып калган.* И. Гази.— *Әйтсәгезче, якын дус итеп, Кайгы белән сулган анага...* М. Җәлил. || *сөйл.* Кимү яки бетү (матурлык һ. б. ш. турында). *Ул ябыккан, агарган, әмма әлекке матурлыгы сулмаган әле.* Каз. утл.

СУЛУ II *и. к.* сулыш (1 мәгъ.). *Заһит тиз генә сулуы белән аны җылытырга тотынды, кош та азрак селкенә башлады.* С. Җәләл. *Мин сулу саен сине көттем, килереңә ышандым.* Д. Аппакова.

◇ **Сулу алу** — *к.* сулыш алу (1—5 мәгъ.). *Үсемлекләрнең тамырлары сулу ала.* А. Алиш. [*Хәлим*], *тәмам хәле бетеп, карга егылды. Ә бераз сулу алгач, --- яралының баш очына килде.* Г. Гобәй; **Сулу кабу** — *к.* сулыш кабу. [*Кәҗәнең*] *сулуы капкан һәм сулыш алган саен борын тишекләре киңәеп-киңәеп китә иде.* И. Гази.

СУЛЫ *с.* **1.** Суы булган, эченә су салынган (савыт-саба турында). *Сулы чиләк. Сулы стакан.* □ *Гафият-улла абзый сулы мичкә белән анда* [*яңгынга*] *кош кебек очып барып җитте һәм яңгынны зурга җибәрмичә сүндереп тә өлгерде.* Г. Әпсәләмов. || Өстендә, эчендә су булган, су җыелып торган (уйсу җир һ. б. турында). *Орлыклар һәр җирдә үсә алмыйлар. Алар фәкать сулы һәм дымлы җирләрдә генә баш калкыта алалар.* Г. Тукай. *Машина сулы чокырларны әйләнеп үтә-үтә авыл арасыннан бормалы шоссе юлына килеп чыкты.* Г. Мөхәммәтшин. || Эшли, су бирә торган (кран һ. б. турында). [*Егет*], *ишек алдында сулы кран бармы икән дип, ак алъяпкычлы кыз янына китте. Кыз белән сөйләшкәннән соң, колхозчы йортында кранның да һәм юынгычның да барлыгын белде.* А. Шамов.

2. Составында су булган, су кушылган (сыеклыклар, эчемлекләр һ. б. ш. турында). *Лампабыз караңгырак яна, улым. Әллә керосины сулырак инде.* Ә. Камал. *Стаканнарым күктер, Эчендә хикмәт күптер; Җәләй картның сулы кымызын Эчеп эченне күптер.* М. Фәйзи.

3. Суга чылатылган, юеш. *Доктор сулы чүпрәкне* [*авыруның*] *маңгаена куя.* Г. Камал. *Җамал әби чуар тавыкны кыртлавыннан биздерергә тотынды. --- Түшен суга тидерде. Тагын бер әмәл тапты, тавыкны сулы кычыткан белән чапты.* А. Алиш.

4. Сусыл. *Алмалар — бик пешкән, татлы, сулы җимешләр иде.* Дәрдмәнд.

СУЛЫГУ I *ф. к.* сулу I (2 мәгъ.). *Аның кайчандыр симез, тулы йөзе хәзер беркадәр сулыккан һәм бушап, салынып төшкән иде.* Н. Фәттах. *Язга таба, бездә ике-өч айлап торгач, Галяның хәле тагын мөшкелләнде. Көннән-көн сулыга, шиңә барды.* Э. Касыймов.

СУЛЫГУ II *ф. к.* сулкылдау. [*Малай*] *сулыгып-сулыгып елап тора иде. Башта миңа ни дип тә җавап бирмәде ул, соңыннан мин аның сулыгу аралаш әйткән өзек-өзек сүзләрен ишетеп калдым.* Ф. Хөсни. *Аның аяк-кулы --- сызлый, һәр буыны сулыгып-сулыгып авырта.* М. Хәсәнов. *Кыз авырды, тәне ут шикелле, Сулыгып-сулыгып тибә йөрәге.* М. Җәлил.

СУЛЫК *и.* Җыелып тора, саклана торган зур су (күл һ. б. ш.). *Колхозларда ясалма сулыклар булдыру.* □ *Сулык булсын дидек, шуңа эшкә башладык; Болындагы уйсулыкта зур күл ясадык.* Н. Арсланов. *Эшелонга каршы йөгерәләр күк Күлләр, таулар, яшел урманнар; Сулыклардан күтәрелә томан, Болыннарга печәнчеләр тулган.* С. Урайский.

СУЛЫК-СУЛЫК *рәв.* Сулкылдап. *Нидидер дару сөрткәч,* [*тешнең*] *сулык-сулык сызлавы кими төште.*

Э. Касыймов. [*Бик нык уңайсызланудан*] *битләрем сулык-сулык яна башлады.* Г. Мөхәммәтшин.

◊ **Сулык-сулык итү (килү)** — сулкылдау. *Кул җәрәхәтем яңарып, сулык-сулык итте.* Н. Исәнбәт.

СУЛЫШ *и.* 1. Организмның сулау эшчәнлеге, хәрәкәте. *Сулыш юлы. Сулыш системасы.* □ *Язгы көннәрнең һавасы сулышны иркенәйтә.* А. Алиш. [*Авыруның*] *теле начар, сулышы тигезсез иде.* Г. Ибраһимов. *Аккан суларында су тәме юк... Һава җитми сулышка.* Ф. Кәрим. || Сулаганда үпкәдән кире чыга торган һава. *Бугазын пешереп чыккан кайнар сулыш дхмәдинең иреннәрен киптерә, суларга ирек бирми, тынын куыра иде.* Г. Бәширов. *Галиулла, тәрәзәдән бозны сулышы белән эретеп, сыңар күз белән карап тора башлады.* И. Гази.

2. *күч.* Берәр табигый яки иҗтимагый күренешнең сизелә, беленә башлавы, якынлашуы турында. *Революция сулышын тою.* □ *Көз сулышы бөдрә каеннарга да орынды.* Г. Әпсәләмов.

◊ **Сулыш алу** — 1) сулау. *Көннең кызулыгы кайта башлаган булса да, сулыш алырга авыр иде.* Ш. Камал; 2) саф һавада йөрү, саф һава сулау; һава алмаштыру. [*Гөлзифа:*] *Әйдә инде, Асия. Бигрәк бөркү монда. Бер генә сулыш алып керик...* Р. Төхфәтуллин; 3) берәр эш эшләп, хәрәкәт ясап хәлсезләнүдән яки көчле дулкынлану-борчылудан соң тынычланып, тигез сулый башлау; хәл алу. *Төтеннән яшьләнгән күзләребезне уа-уа, төтен агымыннан читкәрәк китик. Бераз сулыш алгач, тирә-ягыбызга каранырга тотындык.* Ф. Кәрим; 4) борчулардан-мәшәкатьләрдән арыну, эшләр җиңеләю; хәл, тормыш яхшыру.— *Гомерем буена газап чиктем. - - - Менә хәзер генә сулыш алырга әйтәм бугай.* Г. Ибраһимов; 5) гомумән, иркенләү. *Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һич бер яктан сулыш алырга бирмәделәр. Тик бер-бер авылга чәй эчәргә төшкәч кенә иркенгә чыгаралар иде.* Г. Тукай; 6) гомер итү, көн күрү. *Сөйли Николай заводта көн күрүен, Тормыш читенлеген; Ярлы кешегә, кая барса да, Сулыш алу җиңел түгеллеген.* Ә. Ерикәй. **Сулыш бетү** — 1) *к.* сулыш киселү. *Үлем килми, сулыш бетмәс борын.* Ф. Бурнаш; 2) *к.* сулыш кабу. *Муены кысылудан сулышы бетеп мышкылдаган Торсынбай авызын ачып тирән сулыш алды.* Ф. Кәрим. **Сулыш иркенәю (киңәю, җиңеләю)** — 1) иркенләп, рәхәтләнеп сулый башлау. *Таулардан иртәләрдә хуш исләр килеп, сулышларны киңәйтә башлады.* Г. Газиз; 2) үзеңне иркен, борчусыз хис итә башлау. *Садыйкны „сукин сын, мошенник" дип ташлагач, аның сулышы иркенәеп китте.* Ш. Камал. **Сулыш кабу** — авыр хәрәкәттән, көчле дулкынланудан һ. б. ш. соң: сулыш алу авыраеп, еш-еш һәм өзек-өзек сулау.— *Тыным буыла, сулыш капты.* Г. Бәширов. **Сулыш киселү (өзелү)** — үлү, вафат булу. *Сугыш, ни әйтсәң дә, сугыш инде, Холык ягы начар сугышның; Әллә кайда, ялкын уртасында Өзелүе мөмкин сулышның.* Ә. Ерикәй. **Сулыш өрү** — 1) эшкә һ. б. ш. җанлылык кертү, активлаштырып җибәрү. — *Сез ул кафедрага өр-яңа бер сулыш өрдегез.* А. Расих; 2) рухландырып, күңелне күтәреп җибәрү. *1905 елгы революциянең давылы электән изелеп килгән халыкларга яшәү сулышы өрде.* Г. Бәширов.

СУЛЬФАЗОЛ *и.* Кокк бактерияләреннән булган чирләргә каршы кулланыла торган даруның бер төре.

СУЛЬФАТ *и. хим.* Сульфат кислотасының тозы. *Аммоний сульфаты. Натрий сульфаты. Кальций сульфаты.*

◊ **Сульфат кислотасы** — H_2SO_4; күкерт ангидриды белән суның химик кушылмасыннан гыйбарәт көчле кислота; майлы, төссез сыекча.

СУЛЬФАТЛЫ *с.* Составында сульфат булган, сульфат кушылган-катнашкан. *Сульфатлы җир.* || Сульфат белән эшкәртелеп, шуның ярдәмендә табыла, ясала торган. *Сульфатлы сабын. Сульфатлы целлюлоза.*

СУЛЬФИД *и. хим.* Металл белән күкертнең химик кушылмасы.

СУЛЬФИТ *и. хим.* Сульфит кислотасының тозы. *Натрий сульфиты.*

◊ **Сульфит кислотасы** — H_2SO_3; эремәләрдә генә очрый торган йомшак, көчсез кислота.

СУМ I *и.* 1. Россиядә һәм СССРда: йөз тиенгә тигез төп акча берәмлеге. *Советлар Союзында бәяләр масштабы булып сум хезмәт итә.* Политэкономия.

2. Шушы кыйммәткә ия булган акча (кәгазь яки металл).

СУМ II: сум ите — боттагы һәм кулдагы бүлтәеп тора торган мускул. *Мөлдерәмә чиләкне күтәргәндә аның беләкләрендәге сум ите чукмар-чукмар булып бүртә, тәне пружина шикелле киерелә.* И. Гази.

СУМА *и.* 1. Акчалата булган байлык, милек. [*Әхмәтҗан:*] *Бөләр хәлем юк, улымны өйләндерәм дип, бар сумамнан язар хәлем юк.* Г. Камал. *Гадәттә Юныс бай зур сумалар белән дә бик юмарт кылана.* К. Нәҗми.

2. Хак, гомуми бәя, кыйммәт. *Мидхәт берничә авыл базарыннан аз-маз сату итеп, җыйбәрелгән малның сумасын югалтмыйча алып кайтты.* Ф. Хөсни. || Акчалата тулаем кыйммәт. [*Хөснулла — Садыйкның югалган әйбере турында:*] *Сумасы шактый зурмыни? — Затлы әйберләр бар шул.* Ш. Камал.

СУМАЛА *и.* Сагызга күкерт, балавыз яки башка берәр нәрсә кушып кайнату юлы белән ясалган кара, ябышучан матдә. *Сумала кайнату.* □ *Сүс тишектә үзе генә тормады. Бары сумала эретеп койгач кына,* [*көймә*] *ныгыган кебек булып торды.* Г. Гобәй.

СУМАЛАЛАУ *ф.* Сумала сылау, сөртү яки сеңдерү. *Шпал сумалалау.* □ *Итекләребезгә олтан салганда, без аңа* [*Хөснетдин абзыйга*] *еш кына җеп сумалалап, аңа ничек кенә булса да ярарга тырыша идек.* Г. Галиев. [*Көймәнең*] *төбендәге бер тактасы буйдан буйга ярык. Башка шартларда ул ярыкны тышкы яктан такта белән ямарга, ә эчтән сүс белән ныгытырга, сумалаларга мөмкин булыр иде.* С. Сабиров.

СУМАЛАЛЫ *с.* Сумалаланган, сумала сөртелгән яки сеңдерелгән. *Сумалалы канат. Сумалалы такта.* □ [*Бабай*] *тырышып-тырышып сумалалы җеп очын шомарта.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Гыймади абзый үлгәндә Мәрдигә сигез яшь тулды. Аңа әтисеннән сумалалы озын сүс чыбыркы, юкәдән үрелгән котомкадан башка нәрсә калмады.* Ф. Әсгать. || Сумалага буялган, пычранган. *Әти утыз ел буена үзенең сумалалы, нефтьле бармаклары белән ача-ача саргайтып, чит-читләрен „ашап" бетергән иман шартын* [*китапны*] *актаргалап карады.* Г. Гобәй.

СУМАЛАНУ *ф. сир.* Билгеле бер сумага ия булу, кулга акча төшерү. [*Бәли*] *барган саен сумаланды. Үзенең - - - базардагы кибетен зурайтып, товарларын арттырды, төрләрен күбәйтте.* М. Гафури.

СУМАЛЫ *с.* Сумасы булган, акчага бай. [*Садыйк бай:*] *Сумалырак кешеләр белән әртил-мазар оештырып булса, берәр хикмәт чыгуы да ихтимал.* Ш. Камал.— *Менә шул* [*хатын*] *минем инде сумалы булганымны, шул илле мең сум көмеш - - - акчам булганны белгән.* Г. Газиз.

СУМАСЫЗЛАНУ *ф. сир.* Суман, акчаң бетү; сумасыз калу. *Революциягә хәтле ул кызыл мал белән нык кына сәүдә итсә дә, революция еллары аны сыктылар, ул сумасызланды.* Г. Толымбай.

СУМКА *и.* 1. Букча. *Китап сумкасы. Кыр сумкасы.* □ *Ишектән зур кара күн сумка аскан почтальон килеп керде.* А. Әхмәт. *Каләмемне салдым юл сумкама.* М. Җәлил.

2. *зоол.* Кайбер хайваннарның корсак астында була торган букча сыман куышлык (яңа туган балаларын шунда асрау өчен хезмәт итә).

СУМКАЛЫ *с. зоол.* 1. Сумкасы (2 мәгъ.) булган. *Сумкалы күсе. Сумкалы бүре. Сумкалы имезүчеләр.*

2. *и. мәгъ.* **сумкалылар.** Хәзерге имезүче хайваннарның үз балаларын сумкаларында җитлектерә торган бер отряды.

СУ!ММА *и.* 1. Саннарны, зурлыкларны кушудан соң килеп чыккан сан, нәтиҗә. *Ике сан суммасы. Көчләр суммасы.* □ *Кушылучыларның урыннарын алмаштырудан сумма үзгәрми.* Алгебра.

2. *күч. кит.* Берәр нәрсәнең гомуми микъдары; җыйма зурлык. *Бөтен тырышлыкларның суммасы.*

СУММАР *с. кит.* Кушу нәтиҗәсендә барлыкка килгән, берәр нәрсәнең гомуми суммасын тәшкил итә торган. *Электр станцияләренең суммар куәте.* || Төрләргә аермыйча, гомумиләштереп күрсәтелгән. *Суммар мәгълүмат. Фактларның суммар тасвирламасы.*

СУМСА *и.* Эченә ит белән (яки күкәй белән) яшелчә, җиләк-җимеш, ярма һ. б. ш. салып ясалган вак бөккән. *Күй маенда пешергән сумса.* □ *Гайнижамал иртәнге чәйгә кайнар сумса өлгертер өчен бераз вакыт кухняда савыт-саба рәтләү, камыр әчетеп кую шикелле эшләр белән маташты.* Ш. Камал.

СУМСАЧЫ *и.* Сумса пешереп, шуның белән сатукәсеп итүче. *Хатыны камыр җәя, кызлары суган турый, уллары ит тураклый. Аннары берсе камыр кисә, икенчесе сумса ясый. Урынбай ата учакка ут ягa. --- Эш белән мәш килгән сумсачы карт безне дә онытмый.* Каз. утл.

СУНАР *и. к.* ау II (1 мәгъ.). *Көннәрдә бер көн бер падишаһ сунарга чыккан иде.* Дәрдмәнд. *Кышкы сунар вата кешене; Ярый шунда, булса төшеме.* М. Сөндекле.

СУНАРЧЫ *и. к.* аучы.— *Мин үзем аучы кеше, сунарчы. --- Әллә ничә мең километр урман сукмакларын үттем; кырларда, әрәмәләрдә мин аяк басмаган җир, белмим, бар микән.* Г. Бәширов. *Балык аулап, кышын җәнлеккә капкын куеп, авылның исемле сунарчысы да булып яшәде* [*Локман*]. Ә. Еники.

СУНАРЧЫЛЫК *и. к.* аучылык. *Уразгул атлы дәртле карт аучы аны чаңгыга өйрәтте. Зур таулар, карлы киң урманнар буенча үзе белән алып, җәнлеккә, куян, төлкегә, бүрегә сунарчылык өчен йөрүнең тәмен татытты.* Г. Ибраһимов.

СУПАЮ *ф. диал.* Чырай караңгылану; канәгатьсезлек-ризасызлык, төшенкелек кебек күнелсез хисләргә бирелү. *Бу ел халык гадәттәге төсле түгел. Барысы да супаеп йөри, күп сөйләшми иде.* С. Әдһәмова.

СУ!ПЕР- *кит.* Кушма сүзләрнең түбәндәге мәгънәләрне белдерә торган беренче кисәге: 1) өстәмә, икенчел, мәсәлән, **суперстрат**; 2) төп, баш, мәсәлән, **суперинтендант**; 3) иң югары сыйфатлы яки иң көчле яисә иң өстен, мәсәлән, **суперцемент, суперартиллерия, супертанкер, супермодернизм.**

СУПЕРФОСФАТ *и. махс.* Фосфорлы химик ашлама.

СУППЛЕТИВ *с. лингв.* Мәгънә һәм грамматик форма ягыннан бер үк төркемгә керә торган, ләкин чыгышлары ягыннан үзгә (сүзләр турында). Мәсәлән: „мин", „без" („миннәр" түгел).

СУП-СУЫК *с. Артык. дәр. к.* суык (1 мәгъ.). *Суп-суык көн.* □ [*Муса*] *кран астына керде, пых-пых итә-итә суп-суык су белән билдән арык юынып маташты.* Ш. Маннур.

СУР *и. иск.* Быргы. *Кыямәт көнендә Исрафил сурын өргәч адәмнәр терелеп, кабер өстендә җитмеш ел хәйран булып утырган кебек, „Аркадия" бакчасында (Әхмәт бай йортына каршы) эскәмияләрдә эшсез хәйран булып утыручылар бу ел да күп иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Бер көн, дигән, сур өрерләр! Һәм мәетләр кубарлар! Ничек дип җавап бирерләр? — Гөнаһларын сорарлар!* М. Максуд.

СУРАЮ *ф. сир. к.* серәю.— *Күз алдымда торма, икенде күләгәсе кебек сураеп.* Т. Миңнуллин.

СУРГУЧ, СУРГЫЧ *и.* Тиз эреп, тиз ката торган сумала сыман матдә (берәр нәрсәне пичәтләп ябыштыру, шешә башларына кою һ. б. ш. өчен кулланыла). *Складны сургуч белән пичәтләп бикләү.*

СУРГУЧЛАУ, СУРГЫЧЛАУ *ф.* Сургуч ябыштыру, сургуч белән беркетү. *Җәмил төргәкне сургучлап, үзенең кесәсендә генә йөртә торган җиз пичәтне сукты.* Г. Гобәй. *Дүрт кырыена һәм уртасына сургучлап пичәт басылган бу пакетны күрүгә Идрис, „командующийдандыр әле, информация өчен чакырадыр", дип уйлады.* К. Нәҗми.

СУРГУЧЛЫ, СУРГЫЧЛЫ *с.* Сургуч белән ябыштырылган, сургучланган. *Сургучлы пакет. Сургучлы йозак.* □ *Жандармерия идарәсе канцеляриясенә сургучлы конверт китереп ташладылар.* Г. Минский. [*Профессор*] *тәҗрибәләр уздыру журналын карап утырды. Бу журнал — иң төп документ, монда һәр тәҗрибә уздырылгач ук язып куела. Ул шнур белән бәйләнгән, сургучлы пичәт белән беркетелгән.* А. Расих.

СУРДОПЕДАГОГ *и. махс.* Укытучы, сурдопедагогика белгече. [*Яшь укытучы*] *чукрак-телсезләр өчен укытучылар булдыру эшен дә оештырды, сурдопедагогларның зур группасын хәзерләде.* Соц. Тат.

СУРДОПЕДАГО!ГИКА *и. махс.* Ишетү сәләте начар яки бөтенләй саңгырау балаларны һәм үсмерләрне тәрбияләү-укыту педагогикасы.

СУ!РИК *и.* 1. Составында кургаш булган минерал.

2. Кызгылт буяу (гадәттә бүтән буяуларга, замазкага һ. б. ш. кушып кулланыла).

СУРИКЛЫ *с.* Составында сурик (2 мәгъ.) булган, сурик кушып ясаган. *Суриклы шпаклевка.*

СУРРОГАТ *с.* 1. Азыкны һ. б. табигый әйберне алмаштыра торган, ләкин сыйфаты ягыннан түбәнрәк булган; ясалма. *Суррогат азык. Суррогат май. Суррогат чәй. Суррогат алмаз. Суррогат шикәр. Суррогат ит.*

2. *и. мәгъ.* Шундый ясалма продукт. *Май суррогаты. Кофе суррогаты. Товар суррогаты.* □ *— Мин мин идем, мин кем идем? Ялан аяк брамат, Рәсәй иңләп йөри идем, Ашый идем суррогат.* Н. Исәнбәт.

СУРЫГУ *ф.* Бераз кибү (аяк астындагы сулар һ. б. турында). || Кипшерә төшү (аяк асты һ. б. ш. турында). *Юл сурыкканга күрә, йөрү җиңел булды.* М. Гафури. *Хәдичә тутинең үзенең дә яшелчә бакчасына төшәсе бар иде. Әле анда кояш чыгып, җир өсте бераз сурыккач кына эшкә тотынасы булганга, үзе соңгарак кузгалырга уйлап, боларны озата чыкты.* Г. Бәширов.

СУРӘТ *и.* 1. Рәсем, портрет. *Кош сурәте ясау. Кәгазьгә сурәтләр төшерү.* □ *Күзем дивардагы сурәтләргә төште.* Г. Ибраһимов.

2. Скульптура әсәре, сын. [*Җәлил һәйкәле алдындагы шагыйрь:*] *Нәкъ үзең күк синең сурәтең.* Х. Туфан.

3. Кыяфәт, килеш-килбәт. *Берәүнең сурәтен күз алдына китерү. Көзгедәгечә сурәт. Җияттәге хайваннарның төрле сурәтләргә керүе.*

4. Күренеш, образ. *Бу юлы шәһәрнең реаль сурәте аның күз алдына килеп басты.* Ш. Камал.

5. *иск.* Әдәби образ. *Символик сурәтләр. Сәнгатьчә сурәтләрнең уңышлы эшләнүе. Традицион сурәтләр. Әсәрдәге табигать сурәтләре.* □ [*Матур әдәбият*] *әсәрләрендә сурәтләр өч төрле: аерым шәхесләр, аларның эш һәм хәрәкәтләре, сүзләре; табигать күренешләре; тормыш-көнкүреш күренешләре.* Г. Нигъмәти.

6. *рәв. мәгъ. кит.* **сурәттә**. Хәлдә, рәвештә. *Күңелсез генә сурәттә чәй эчеп тәмам иткәч, Шәриф дәхи эш эзләп чыгып китте.* М. Гафури. || Берәр формада. [*Кояштагы*] *таплар төрле сурәттә вә зурлыкта булалар.* Ф. Әмирхан.

7. *терк. мәгъ. кит. -ган формасыннан соң.* Гадәттә „да" яки „генә" кисәкчәсе алдыннан: „очракта" дигәнне яки „әгәр" мәгънәсен белдерә. *Көн аяз торган сурәттә игенне тиз җыеп була.* Сойләмнән. *Атасы аннан куып чыгарган сурәттә дә Нәфисә --- барыбер үкенмәгән булыр иде.* Г. Бәширов. *Ул мондый эшкә ким дигәндә дүрт ай вакыт кирәк булуын, директорның сүзен аяк астына салмыйк дигән сурәттә дә --- ял дигән нәрсәне онытып торырга туры киләчәген уйлады.* Каз. утл.

СУРӘТЛЕ *с.* Сурәтләр (1, 2 мәгъ.) белән бизәлгән. *Сурәтле стена. Сурәтле китап.* □ *Хәят, ялкау гына өстәл өстендәге сурәтле журналны алып, сурәтләре өстеннән тиз-тиз генә күз йөртеп чыгарга* [*кереште*]. Ф. Әмирхан.

СУРӘТЛӘМӘ *и.* Сурәтләр, образлар ярдәмендә бирелгән тасвирлама; читләтеп-кинаяләп тасвирлау алымы. *Табышмакларның төрле сурәтләмәләргә бай булуы.* □ [*Кайбер*] *мәкальләрдә нинди дә булса шигъри күренешләр, кинаяле сурәтләмәләр күренми, алар кыска-кыска гына итеп кешегә турыдантуры бирәр тәҗрибә, акыл яки киңәш бирәләр.* Н. Исәнбәт.

СУРӘТЛӘҮ *ф.* I. Сурәт (яки сурәтләр) белән бизәү. *Стеналарны сурәтләү.*

2. Тасвирлау. *Әдәби әсәрдә төрле күренеш һәм хәлләрке сурәтләү. Геройларны җанлы итеп сурәтләү. Сурәтләү чаралары.* □ *Тукайның Казанга килгән вакыттагы кыяфәтен атаклы язучы Фатих Әмирхан шулай сурәтли: „Кыска буйлы, чандыр гәүдәле..." М. Гали. Ярлыларның хәлен М. Гафури үзенең „Ярлылар, яки өйдәш хатын" дигән көчле чәчмә әсәрендә бик җанлы сурәтләде.* М. Җәлил.

СУРӘТЧЕ *и. сөйл.* Сурәт (1, 2 мәгъ.) ясаучы; скульптор яки художник. [*Кошның*] *койрыгындагы күз-күз түгәрәк бизәкләре бик оста сурәтче кулы белән ясап куйган төсле.* Ә. Фәйзи.

СУСАР *и. зоол.* Кыйммәт мехлы кечерәк кенә имезүче хайван; *русчасы:* куница.

СУСАТУ *ф. Көкл. юн. к.* сусау. || *з-сыз.* Эчәсе килү турында.— *Куа төш, егетем, бик сусатты,— дигән булды* [*утырып кайтучы*]. Г. Гобәй.

СУСАУ *ф.* **1.** Эчәсе килүне тою; тамак кибү. *Болыннан ул бик сусап, тамагы кибеп кайткан иде.* Э. Касыймов.— *Сусадым мин, миңа су биregez.* Ф. Бурнаш.

2. Дымга, яңгырга мохтаҗ булу (үсемлекләр турында). *Сабаннар бик сусады, бәрәңгеләрнең дә чәчәкләре көя; яңгыр бик кирәк.* Р. Төхфәтуллин. *Давыл котырды-котырды да бара торгач әкренләп тына-тына, яңгырга сусап, кибеп калган җир йөзенә бер генә тамчы да төшермичә, бөтенләй туктап калды.* Г. Иделле.

3. *күч.* Юн. килештәге сүздән соң: шуңа ихтыяҗын көчле булу, шуны бик теләү, шуңа омтылу. *Белемгә сусау. Яңа хәбәрләргә сусау. Мәхәббәткә сусау.* □ *Халыкның әдәбиятка, театрга сусавы бик үсте.* Н. Исәнбәт. *Аның бу сүзләренең төбендә чын азатлыкка сусау, зур эшләргә омтылу сизелә иде.* С. Сабиров. *Без яшь әле, бик яшь әле, Яшәүгә сусый йөрәк.* Г. Хуҗи.

СУСЫЗ *с.* **1.** Суы булмаган, эченә су салынмаган (төрле савыт-саба турында). *Сусыз стакан. Сусыз чиләк.*

2. Суы беткән, кипкән (төрле сулык турында). *Авылның нәкъ уртасыннан зур гына сусыз елга ярып үтә.* Р. Төхфәтуллин. *Бер дә бер көнне ике агай-эне юл чыктылар. Юлларында ике күл очрады: берсе сусыз, берсе коры.* И. Гази.

3. Судан, дымнан мәхрүм (төрле җирләр, бигрәк тә чүлләр турында). *Сусыз болын — көйгән дала, кипкән тугайлар.* Н. Арсланов. *Безнең замана, Яңа юлга борып дәрьяны, Җәннәт итә сусыз даланы.* Х. Туфан.

СУСЫЗЛЫК *и.* **1.** Сусыз булу хәле.

2. Суга-дымга мохтаҗлык; корылык. *Көн шундый кызу, --- туфракка басар хәл дә юк. Инеш буендагы талларга хәтле, яфракларын коеп, сусызлыктан көйрәп утыралар.* К. Нәҗми. || Бик сусау хәле. *Сулары бызы, азыкларыбыз бетте һәм байталларыбызның җәгәре калмады, шул хәлдә минем юлдашларым һәммәсе ачлык һәм сусызлыктан һәлак булдылар.* Ф. Халиди.

СУСЫЛ *с.* Эчендә суы чагыштырмача күп булган (үсемлек, мал азыгы һ. б. турында). *Сусыл чирәм. Сусыл печән. Сусыл алма.* □ *Зиратта мул булып үлән үскән. Сусыл сабаклы әнисләр чәчәк атканнар.* А. Гыйләҗев. *Турнепс та, гәрәңкә дә, кишер дә, бакчада өлгерә торган яшелчәләрдән кабак та, карбыз да иң тәмле азыклардан санала. Болар барысы да сусыл азыклар. Аларда су туксан процентка кадәр җитә.* А. Расих.

СУСЫЛЛАНУ *ф.* Сусылга әйләнү. *Җиләк-җимешнең сусыллануы.*

СУСЫЛЛЫК *и.* Сусыл булу үзлеге һәм хәле. *Силосның сусыллыгы.*

СУСЫН *и.* Эчәсе килү тойгысы, тамак кибү халәте. *Квас эчкәч сусын басылу.* □ *Һава шактый бөркү иде; шуңадыр инде, куе чәй аеруча тәмле, эчкән саен сусын ачыла гына бара иде.* Ә. Еники.

СУТ *и.* Үлән күзәнәкләрендәге ябышучан сыекча, су; үлән сүле. [*Үләндә йөгерешеп йөрүче нәниләрнең*] *яшел үлән сутына буялган тәпиләре һәм йомшак артлары гына елт-елт күренеп кала.* Каз. утл.

СУТКАК *и. сөйл.* Сутлы балчык. *Бала-чаганың суткактан сыннар ясап уйнавы.* □ *Яланбаш булганга [яралының] чәчләре белән бергә йөзләре дә --- күл төбенең чем-кара торфлы суткак пычрагы белән капланып каткан иде.* Ш. Маннур.

СУТЛЫ *с.* Үзле, дымлы һәм бераз лайлалы (балчык турында). *Балалар шул чишмәләрне сутлы балчык белән бөяп уйныйлар.* Ә. Камал.— *Кешеләр, эленке-салынкы булып, аяклары сутлы балчыкка баткандай, көчкә генә өстерәлеп баралар.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

СУФИ *и. иск.* **1.** Тормыштан, дөньядан ваз кичеп, гомерен аллага, дингә хезмәт итүгә багышлаган мөселман. [*Ишанның*] *тирә-ягында ярдәмче хәлфәләре, суфилары бик күп. Боларның кайберсе кунакларга чәй ясый, кайберәүләре шундагы халыкны утыртып, тәртип саклап йөри.* М. Гафури. *Әхмәтҗан карт, әкрен генә кибетен ябып өенә кайтканда, --- чатта утырып, бер туктамый селкенеп, әллә нәрсәләр укый торган суфига кесәсеннән чыгарып биш тиен акча биреп, ике тиен сдача алды.* Г. Газиз.

2. *с. мәгъ.* Бик динчел булып кыланучы, изге булып күренергә тырышучы. *Суфи кеше. Суфи карт.* □ *Суфилыкка Сафи абзый суфидыр, һәр намазын соңга калмый укыйдыр.* Г. Тукай. *Фәтхулла тыштан бик динчел, суфи кеше булып йөри. Ул хәтта үзе тавык та суймый иде.* Г. Иделле. || Суфичылыкны алга сөрүче, пропагандалаучы (әдәби юнәлеш, язучы һ. б. турында). *Борынгы татар һәм төрки поэзиясендә мондый [каршы куюлы] тасвир киң кулланылган; аның алымнары, формасы шактый эшләнгән, чарланган булган. Бу бигрәк тә суфи шагыйрьләрдә шулай.* Х. Госман.

СУФИЛАНУ *ф.* Суфи, изге кеше булып, яхшы булып кылану. *Бик ашыйсы килсә дә һәм барса да ачтан үлеп, Сузыла ул ашка ашыкмый, бик суфиланган булып.* Г. Тукай. [*Хафиз*] *мәхәллә халкы алдында дәрәҗәсен күтәрергә һәм суфиланып, итагатьлек күрсәтеп, хәзрәткә елышырга тырышты.* Ә. Еники.

СУФИЛЫК *и.* 1. Суфига хас сыйфатлар; суфи булу хәле.— *Суфилыгын күрсәтер өчен мыегын борын астыннан үк кырадыр, Кеше күрмәгәндә эчкәне аның — сырадыр!* Ш. Мөхәммәдев. *Тыштан суфилык сатып йөрүче сәүдәгәр Сиражиның бөтен теләге шуның белән [дөньяда рәхәт яшәп калу белән] төгәлләнә.* М. Гали.

2. *к.* суфичылык. *Безнең әдәбиятның борынгы ярым гарәпчә, ярым госманлы, чыгтайча, борынгы төрки телле динлек, суфилык, ишанлык белән тулы әдәбияты --- —феодализм калдыгының турыдантуры җимешләре.* Г. Ибраһимов.

СУФИЧЫЛ *с.* Суфилыкны һәм суфичылыкны яклый, шуңа иярә торган. *Суфичыл карашлы булу гына, мәсәлән, Тажетдин Ялчыголга тарихи әсәр язуга комачаулык итмәгән.* Каз. утл.

СУФИЧЫЛЫК *и.* Суфилар карашы, идеологиясе. *Суфичылыктан азат булу. Суфичылыкны алга сөрү.* □ *Схоластик мәктәпләрнең укучылары арасында бунтарь элементлар күбәя башлый. Әдәбиятта суфичылык өйрәтмәләренә капма-каршы идеяләр үсә, гуманистик традицияләр яңара башлый.* Х. Госман.

СУФЛЁР *и.* Тамаша вакытында артистка аның сүзләрен (репликаларын) әйтеп торучы сәхнә хезмәткәре. *Һәр каләм тоткан кеше әдәби, шигъри нәрсә яза алмаган һәм һәр пумала, буяу белән маташкан кеше рәссам-сәнгатькәр була алмаган кебек, укый-яза белгән, суфлер артыннан тутый кош кебек әйтеп барган бар кеше дә артист вә артистка була алмый.* Ш. Әхмәдиев. *Өстәл астына кереп утырган суфлер бөтен „залга" ишетелерлек итеп өч тапкыр кабатлагач кына, Хәлим, бераз аңына килеп, пьесаның беренче сүзләрен әйтте.* И. Гази.

СУФЛЁРЛЫК *и.* Суфлер хезмәте, суфлер вазифасы.

СУ'ФФИКС *и. лингв.* Сүзнең тамыры белән төрләндергеч кушымча арасында тора торган ясагыч кушымча.

СУЧЫ *и.* Су ташу, су белән тәэмин итү эшләрендә эшләүче. *Каравылчы, капканы киң итеп ачып, сучыны кертеп җибәрә.* Ф. Хөсни.

СУШИ'ЛКА *и.* Ашлык һ. б. нәрсә киптерү өчен махсус җайланган һәм җиһазланган каралты яки аппарат, машина һ. б. ш. *Ашлыкны сушилкада киптерү. Барабанлы сушилка.* □ *Амбарларга, сушилкаларга вак-төяк төзәтүләр кирәк булачак.* Т. Гыйззәт.

СУЫК *с.* 1. Чагыштырмача түбән температуралы. *Суык көн. Суык бүлмә. Суык су. Суык һава.* □ *Ябылмыйча калган ишектән суык җил керә.* М. Җәлил.

2. Кайнарлыгы яки җылылыгы беткән, суынган (аш-су турында). *Суык чәй.* □ *Булат алдындагы суык каз итен кискәләргә пычак сорап алды.* Г. Ибраһимов.

3. *күч.* Кырыс холыклы, артык рәсми мөгамәләле, ягымсыз. *Суык кеше.* || Кырыс, артык рәсми, ягымсыз (мөгамәлә, караш һ. б. ш. турында). *Суык мөгамәлә. Суык чырайлы байбикә.* □ *— Соңга табарак Гөлнарымнан ничектер суыграк хатлар ала башладым.* Ә. Айдар. [*Шагыйрь — чибәр кызга:*] *Нигә суык матурлыклар белән Кайнар күкрәгеңне бизәргә?* Ә. Кари. *Суык сүз — җангадыр агу.* Г. Кандалый.

4. Җылылык чыгармый яки җылылык чыганагы була алмый яисә җылылыгы сизелми торган (төрле җисемнәр, нурлар һ. б. турында). *Суык йолдызлар.*

5. *сөйл. к.* салкын (7 мәгъ.).

6. *и. мәгъ.* Салкынлык; түбән температура; суык һава. *Суыкка чыдам булу. Февраль суыгы.* □ *Менә тиздән килер суыклар.* М. Җәлил. *Киндер тукып беткәч, аны суыкка чыгарып туңдыра, кар өстенә җәя башладылар.* Дәрдмәнд. *Буяулы идәндә аягыма суык бәрә, туңа башлыйм.* С. Җәләл.

◇ **Суык алдыру (тидерү)** — суык тәэсиреннән чирләү, чирли башлау. *Озак су коенып суык алдыру.* □ *Корбангали карт бүлмә астындагы куышларны төзәтә-төзәтә суык тидереп үлгән.* Ш. Камал. **Суык алу** — *к.* суык тию. [*Карчык:*] *Дә бәпкәм, бер аягың җирдә, икенчесе кабердә булгач, җәй көне дә суык ала икән.* А. Әхмәт. **Суык аяк** — җиңел кәсеп эзләп йөрүче кеше, зимагур, сукбай. *Элек, без яшь чакта үк әле, ул якларга рәтле кеше аяк басмады. Диңгез матурлыгы, балык, фәлән-фәсмәтән дип юкка хыялланып йөрүче төрле суык аяк, зимагурлар гына алданып китәләр һәм ник барганнарына үкенеп, тәмам өтелеп кайта торганнар иде.* С. Сабиров. **Суык бабай** — *к.* кыш бабай. *Суык бабай, кил безгә Яңа ел бәйрәменә.* М. Җәлил. **Суык канлы** — *к.* салкын канлы. *Йосыфҗан — акыллы, суык канлы, нечкә аңлы, зирәк-тырыш, ләкин гажәп эгоист табигатьле бер егет.* Г. Ибраһимов. **Суык тию** — суык тәэсир итеп, чирләү.— *Суык тиеп үләрсең бит, юләр!* Т. Гыйззәт.

СУЫКЛАНУ *ф. к.* суыну (1, 2 мәгъ.). *Көн суыклану. Үзара мөнәсәбәтләр суыклану.* □ *Әңгәмә ниһаять үзенең кабыгын сала башлады, һәм әле генә шундый тыныч яңгыраган басынкы тавыш корылана, суыклана барды.* К. Нәҗми.

СУЫКЛАТУ *ф. к.* суыту (1, 2 мәгъ.). *Җитәр инде, кышның көне күп суыклатты,— ди, җәелеп агып ята торган елга әйтә.— Инде торып эшкә ябышырга вакыт.* С. Җәләл.

СУЫКЛЫК *и.* Суык булу хәле; түбән температура. *Суыклыкка түзә алмау. Кышның суыклыгы.* □ *Көннең суыклыгына карамастан, алырга килүче егет чыкмәнен җилбәгәй җибәргән иде.* М. Гали. *Анда ачлыктан, суыклыктан Туганнарым минем, Бер-беренә сарылышып, ярдәм көтәләр.* Һ. Такташ.

2. *күч.* Ошатмау-яратмауга нигезләнгән мөнәсәбәтне чагылдыра торган хис. *Түрәнең үзеннән түбәннәргә карата суыклыгы. Мөгамәләдәге суыклык.*

СУЫКСУ, СУЫКСЫНУ *ф.* Тәндә бераз салкынлык тою, әз генә туңып тору. *Бер куанам, Бер оялам, Бер суыксып китәм, Бер янам.* Ш. Маннур. *Ул тәне суыксып торудан зарланып алды, көзен-кышын өстеннән төшми торган җәйге зәңгәр пальтосын киде.* С. Рафиков.— *Әллә нигә аркам суыксып тора.* А. Гыйләҗев. *Мәдәния суыксынгандай бөрешә төшеп ике кулын күкрәгенә кысты.* Г. Бәширов.

СУЫНДЫРУ *ф. к.* суыту (1, 3 мәгъ.). *Бүлмәне суындыру. Суны суындыру.* □ *Әгәр син аны шулай төртеп җибәрсәң, ул үзен үзе сөючән яшь баланың бөтенләй күңелен суындырып, үзеңнән еракландырырга сәбәп булырсың.* Г. Тукай.

СУЫНУ *ф.* **1.** Салкын хәлгә килү, салкынаю. *Мич суыну.* □ *Кояш бакчалар артына төшеп бара; һава суынды.* И. Гази.— *Әйдә, аш суына, ашап алыйк.* Т. Гыйззәт.— *Самоварың суынып беткәндер инде.* М. Фәйзи. || Кызган, эсселәгән хәлдән чыгу; эсселәве бетү.— *Хәзер солы бирергә ярамый әле [атка]. Бераз суынсын; коры печән булганда, бераз бирергә ярый.* Ш. Камал.

2. *күч.* Берәр нәрсәгә яки кешегә карата кызыксыну бетү, аның белән мавыкмый башлау, аннан читләшү, бизү. *Валентин кызны эзләү дәртеннән шушы көнгә кадәр суынмады.* Ш. Бикчурин. [*Зәбәрҗәт*] *Заһитнең җәй башыннан бирле ничектер үзенә карата суынганлыгын тойды.* А. Расих. || Бетү яки кимү, сүрелү (хис, дәрт һ. б. турында). *Малайларның балык тоту дәрте суына төште.* Ә. Фәйзи. *Яулык уңмас, дуслык сулмас, Чын мәхәббәт суынмас.* Ә. Ерикәй. || Рухи тынычлану; дулкынланудан туктау. *Бу авыр кичерешләрдән бераз суынырга, айнырга кирәк иде аңа.* Г. Минский. *Аның тиз мавыгып, тиз суынучан холкын элек тә беләләр иде.* К. Нәҗми.

3. *күч.* Актуальлеге, кызыгы бетү, онытыла башлау (эш, мәсьәлә һ. б. турында). [*Халидә*] *бу мәсьәләгә суынырга һич тә ирек бирми, тимерне кызганда сугып калырга итә.* Ф. Хөсни.

СУЫРГЫЧ *и.* **1.** Ашлык суыра торган авыл хуҗалыгы машинасы, җилгәргеч. *Суыргычлар җитез әйләнә. Чистартылып чыккан орлыкларны кешеләр капчыкларга тутыра, машиналарга төйи.* С. Рафиков.

2. Суырта торган машина, аппарат, җайланма. *Тузан суыргыч.* □ *Ак кабаклардай нефть баклары күзгә чагылды. Монда инде табылган нефтьне бакларга җыялар һәм автомат суыргычлар ярдәмендә ерак-еракларга озаталар иде.* А. Расих.

СУЫРТКЫЧ *и.* **1.** Суырту (I) җайланмасы, механизмы. *Ул вакытта бу кечкенә генә бухтада иренеп кенә эшләүче җир суырткыч машина тавышы белән үзәнлектә җилләр уртасында калган иске тегермән ыңгырашканы гына ишетелә иде.* Каз. утл.

2. *к.* киптергеч. *Дәфтәр суырткычы.*

СУЫРТУ I *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* суыру I (1, 2, 4—6, 9, 11 мәгъ.).

2. Насос һ. б. җайланма ярдәмендә суыру (1, 6 мәгъ.). *Мичкәдән шланг белән керосин суырту. Идән астына төшкән суны насос белән суыртып түгү. Машина белән тузан суырту.* □ *Әнә анда ак калайдан эшләнгән бал суырту машинасы әйләнә. Күзәнәкләрдәге сыек бал, суырту көченә каршы тора алмыйча, машина стенасына сибәли.* А. Алиш. [*Рәхим*], *кулына шприц алып, аңа эремә суыртты.* А. Расих.

СУЫРТУ II *ф. Йөкл. юн. к.* суыру II. || Суыргыч машина ярдәмендә суыру (II), эшкәртү. *Ашлык суыртту.* □ [*Колхоз председателе — Мәрьямгә:*] *Иртәгә кибәк суыртырга әндәшүем.* С. Шәкүров.

СУЫРУ I *ф.* **1.** Һава агымы белән эчкә тартып алу. *Ул папирос кабызды һәм аны тирән итеп суырды.* А. Шамов.

2. Иренне кыскан килеш әз-әзләп авызга алу, эчү. *Җимеш суын суыру.* || Имү. [*Колын*] *бик ачыгып туган күрәсең, әнкәсенең сөт тулып каткан имчәкләрен суырып азаплана.* Г. Ибраһимов. *Сөтсез имчәкләрен суыра-суыра Елый аның сабый баласы.* Ә. Ерикәй. || Авызга кабып, суыргандай, имгәндәй итү (бармакны һ. б. нәрсәне). *Чүкеч тиеп авырткан бармагын суырып торган Илдар, әллә ишетмәде, әллә ишетеп әһәмият бирмәде, әнисенә күтәрелеп карамады.* Г. Гобәй. || Организмдагы кан, сүл һ. б. ш. сыекчаны имгечләре белән эчү, эчкә алу (бөҗәкләр, җәнлекләр турында). *Юл читендәге тукранбаш чәчәгендә --- төклетура тәмләп кенә бал суырып маташа.* Г. Бәширов. *Каныңны суырырга кунган черкине сытасың.* Т. Миңнуллин.

3. *күч. сир.* Ябыктыру, зәгыйфьләндерү (борчу, кайгы һ. б. турында). *Бу тормыш аны башка шәкертләр кебек үк, суырган; тумыштан таза, киң күкрәкле һәм гайрәтле бала саргаеп кипкән егет хәленә әйләнергә якын иде.* Г. Ибраһимов.

4. *күч.* Көчләү, мәҗбүр итү һ. б. ш. юл белән берәүдән яки берәр җирдән берәр нәрсә алып тору, аны табыш чыганагы итеп файдалану. [*Зариф:*] *Мәскәүгә барып әйбәтләп урнашырбыз. --- Акчалата без аңардан [бай инженердан] суырып торырбыз.* Ш. Камал. *Баязит әйтә иде, өйрәнмәгәнрәк тоткыннарның серләрен алыр өчен күрше камерага охранка агентын утырталар да, стена аркылы шулай сөйләтеп, материал суыралар ди торган иде.* Г. Ибраһимов.

5. Авыз эче, тел һәм иреннәр белән кысып-әвәләп, ялап әретү һәм йоту. *Әхмәди шикәрне суырып балалар сыман иреннәрен ялмагач, телен чартлатып куйды.* Г. Бәширов. *Ул әле күптән түгел генә тартуын ташлаган, ләкин янындагы кешеләр тартканда күңеле кытыклана, шуңа конфет суыра иде.* С. Рафиков.

6. Һава агымы ярдәмендә берәр җирдән агызып, тартып чыгару (насос һ. б. ш. турында). *Тавышсызтынсыз гына җир астыннан нефть суыручы ап-ак фонтан арматуралары [күренде].* А. Әхмәт. || Эчендәге нәрсәсен (җелеген, төтенен һ. б.) һава агымы белән тартып-иәртеп чыгару, эчкә алу. *Дәүләтъяров сөяк суыручы Курманаевка --- мөрәҗәгать итмичә гел йорт хуҗасына карап сөйләде.* И. Гази.— *Йомырканың коры кабыгы гына калган, эчен нәрсәдер бик чиста итеп суырып алган.* А. Алиш.

7. Үсемлекнең җирдән-судан азык алуы турында. *Үсемлек үзенең тамырлары аша җирдән суырып ала [азыкны].* А. Расих.

8. Үз эченә тартып кертү, батыру (сазлык, упкын һ. б. ш. турында). *Бөтерелеп-кайнап торган упкынның су коенучыларны суыруы.* □ *Бетте алаша, Сиваш суырды үзен, йотты.* Г. Бәширов. *Кышкы салкыннар да, тездән суыручан язгы пычраклар да, әлсерәткеч җәйге эсселәр дә куркыта алмадылар [чирәм җирдә эшләүчеләрне].* М. Хөсәен.

9. *күч. сөйл.* Берәр нәрсәнең көч-куәтне, чыгымны бик күп алуы турында. *Туйның акчаны күп суыруы.* □ [*Мәхәббәт борчулары*] *үзәкне өзәләр, күңелсезләндерәләр, көчне суыралар.* Г. Әпсәләмов. *Төзелеш бит, шул суырды инде аны [акчаны].* Каз. утл.

10. Һава агымы ярдәмендә төтенне яхшы үткәрү; тарту (моржа һ. б. турында). *Ул, улы белән бергәләп, мичнең бер өлешен сүтте, төтен юлларын көлдән, корымнан арчыды, аларның ныклыгын, суыру көчен тикшерде.* А. Шамов.

11. Тыгып, кидереп, кагып куелган урыннан тартып, йолкып чыгару. *Киртә казыгын суыру. Кадак суыру. Бармактагы йөзекне суырып алу. Кылычны кынысыннан суырып чыгару.* □ *Кайсыдыр утынга дип читәнне суырырга тотынды.* И. Гази. *Тез башына куеп официант Бөке суыра бөтен көченә.* Ф. Кәрим. || Үсеп утырган җиреннән йолкып чыгару. *Үсемлекне тамыры белән суырып алу. Авыртканы тешне суыру.* □ *Фашистлар аны шулай таң аткан чы азаплаганнар. --- Тырнакларын суыра башлаганнар, аркасыннан тасма-тасма тиресен телеп алганнар.* Г. Бәширов.

СУЫРУ II *ф.* Җил яки суыргыч ярдәмендә кибәктән, чүп-чардан аерып чистарту; җилгәрү (ашлыкны). *Көндезге аш вакытында Сафа суыру машинасының иләкләрен рәтләргә дип ындырда бер үзе калды.* А. Шамов. *Көндез суккан ашлыкларны кичен бергә*

җыеп көшелгә өябез. Эти шуларны җил уңаена торып көрәк белән суыра. З. Бәширн.

СУЫРЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* суыру I.

2. *күч.* Ябыгу; кечерәеп, нечкәреп калу. *Чак кына сизерлек суырылу шулай ук йөзендә дә күренә [кызның], ияге очлаеп, ирен һәм авыз сызыклары тирәнәя төшкән.* Ф. Хөсни.— *Синең ялганыңны сизгәннән соң мин ябыктым, суырылдым.* Г. Кутуй.

СУЫТКЫЧ *и.* **1.** Берәр нәрсәне суыту өчен хезмәт итә торган махсус җайланма, аппарат. *Пар машинасының суыткычы. Прокатлау станындагы суыткыч. Су суыткыч.* □ *Кабиналарда температура күтәрелгәннән-күтәрелде. Тирләп-ныап пешкән сәхәтчеләр барлык суыткычларны әшкә җиктеләр, ләкин бу да артык ярдәм итмәде.* А. Тимергалин. *Урта бер җирдә гаять зур урынны биләп акка буялган цистерна-термос тора. Аның як-ягында сөт суыткычлар.* М. Хәсәнов.

2. Ясалма рәвештә түбәнәйтелгән температуралы махсус шкаф, бүлмә, җайланма һ. б. (азык әйберләрен суыту, туңдыру, саклау һ. б. ш. өчен хезмәт итә). *Итне-майны суыткычка куеп саклау.* □ *Стена буендагы зур суыткычтан кыз бер кисәк колбаса китерде.* А. Расих.

3. *с. мәгъ.* Суыту өчен хезмәт итә торган. *Өйнең бер бүлмәсендә электрон плитә белән суыткыч җайланма, икенче бүлмәсендә ванна бар иде.* Н. Фәттах. *Цехларның һәр почмагында, һәр җирендә хезмәт кайный. --- Түшәмгә асылмалы краннар беркетәләр, станоктан станокка суыткыч сыекча бирү өчен металл торбалар уздыралар.* А. Расих.

СУЫТУ *ф.* **1.** Суык яки суыграк хәлгә китерү, җылылыгын яки кайнарлыгын-эсселеген бетерү яисә кимәтү. *Ашны суыту. Кызган тимерне суыту. Ишектән артык еш кереп-чыгып өйне суыту. Суыту җайланмасы.* □ *Садыйк бал калагы белән чәйне суыта-суыта үзенең тартып чыгарган кәгазьләреннән берсен укырга тотынды.* Г. Ибраһимов. || Кызганлыкны, эсселәгәнлекне бетерү яки басу. *Атларны тугарып, суытырга бәйләп куйдык.* М. Гафури.

2. Суыну, салкынаю (көн, һава турында). *Көн суытыр чамасы.* Ш. Камал. *Кич булу белән һава суыта төшкән. Күк йөзе ачылган, йолдызлар калыкканнар.* Ә. Еники. || *з-сыз.* Көннең суынуы, салкынаюы турында. *Өч көн өзлексез яңгыр яуды-яуды да, кинәт суытып җибәрде.* Д. Аппакова. *Тышта тагын да суыта төшкән бугай.* К. Нәҗми.

3. Бетерү яки киметү, сүрелдерү (мәхәббәт, дәрт, ярсуны һ. б.). *Хәлимнең фронтка китү дәртен сүзләр белән генә суыта алмагач, үз яныннан җибәрмәү чарасына кереште [әтисе].* Г. Гобәй. *Аның сабыр, тыныч карашы Гәрәйне дә бераз суытты.* А. Гыйләҗев.

4. *күч. сөйл.* Урлау.

СУЮ *ф.* **1.** Бугаз кисеп, канны агызып үтерү. *Мал суя торган пычак. Сугым сую.* □ *— Әле уракка чыгар алдыннан гына бер сарык суйган идек, тагын бер тәкә, бер тана, үгез суясыбыз бар.* Ш. Камал. || Гомумән, үткен корал белән чәнчеп, кадап үтерү. *Фашистлар безнең совет иленә басып кереп, кешеләребезне суя, шәһәрләребезне, авылларыбызны яндыра башлады.* Г. Бәширов.

2. Кан чыгар дәрәҗәдә ышкытып кырдыру, җәрәхәтләү, чиләндерү (тәнне). *Итекләр үкчәне суеп бетерделәр.* Р. Батуллин. *Таякның сындырылган кытыршы башы уч төбен суйды. Чип-чи кан.* М. Хәсәнов.

3. *күч. сөйл.* Иң җаваплы, хәлиткеч берәр вакытта тоткарлык һ. б. ясап, бик уңайсыз хәлгә кую.— *Суйды бит ул юньсез үзенең урынсыз соравы белән!* Ә. Еники. || Нык җәфалау, газаплау. [*Русча белмәүче солдат:*] *Бу „Отче наш"лары белән суялар бит, Сәфәр малай.* Ф. Хөсни.

4. *диал.* Тунау; тирене аерып җәрәхәтләү. *Дошман солдатлары ак каенга Чибәр кызны бәйләп куйдылар. Каен тузы кебек тиресен суеп, Күкрәгенә йолдыз уйдылар.* Ә. Ерикәй.

5. *диал.* Каезлап, кәүсәсеннән аеру, куптару (агач кабыгын). *Эшләп ашагыз дигән сүзне ишетергә туры килгәнгә, әнемне иртәп, тал кабыгы суярга йөри башладым.* М. Гафури.

◇ **Суеп каплаган кебек, суйган да каплаган** — 1) нәкъ үзе, бик охшаган. *Дускаев суеп каплагандай үзенә охшаган --- туп шикелле малаен бер дә яныннан җибәрми.* Ә. Еники; 2) бик туры килә, җавап бирә, яраша торган. *Аның исеме Агзаметдин, ләкин аны үз артында бөтен авыл халкы Аждаһетдин дип атый. Исеме гажәп туры килгән. Суйган да каплаган! Каян тапканнар!* А. Шамов.

СУҮСЕМ *и. бот.* Тамыр, сабак һәм яфракка аерылмаган, түбән төзелешле су үсемлеге; *русчасы:* водоросль. *Суүсемнәр белән туенучы диңгез хайваннары.*

СФЕРА *и.* **1.** Геометриядә: барлык ноктaлары үзәктән тигез ераклыкта булган йомык өслек, өсйөз.

2. *кит.* Берәр нәрсәнең тараду-урнашу һәм тәэсирхәрәкәт итү өлкәсе. *Җирнең тарту көче сферасы.* || Эшчәнлек һ. б. ш. өлкәсе; мохит. *Халыкара йогынты сфералары өчен көрәш.* □ *Тарихи үсешнең хәзерге этабында экономика сферасында социализм белән коммунизмның кискен бәрелеше бара.* Соц. Тат.

СФЕ'РИК *с.* **1.** Сфера (1 мәгъ.), шар өсйөзе формасындагы. *Сферик өсйөз. Сферик пыяла. Сферик гөмбәз.*

2. *мат.* Сфера (1 мәгъ.) эчендә яки сферик өсйөз өстендә урнашкан. *Сферик сектор. Сферик өчпочмак.* || Сферага (1 мәгъ.) мөнәсәбәтле; шундый җисемнәрне, формаларны тикшерә торган. *Ноктаның сферик координаталары. Сферик тригонометрия.*

СФИНКС *и.* **1.** Борынгы Мисырда: сузылып яткан арыслан кыяфәтендәге кеше башлы сын. *Карнак белән Луксор гыйбадәтханәсе арасында борын заманда сфинкслар аллеясе булган. Анда биш йөз сфинкс тезелеп торган.* Каз. утл.

2. Борынгы грек мифологиясендә: арыслан аяклы, елан койрыклы, канатлы хатын-кыз (яки хатын-кыз башлы, канатлы арслан) кыяфәтендәге зат.

СХЕ'МА *и.* **1.** Берәр нәрсәнең төзелешен гадиләштереп күрсәткән сызым; төзелеш формасы. *Станок схемасын сызу. Төзелеш урынының схемасы.* □ *— Күп кенә фермаларда үрдәк бәпкәләре өчен автоэчергечләр куелган икән. Аларны безнең фермаларда да җайлаштырырга мөмкин булачак. Миндә моның өчен әзер схема бар.* М. Максуд.

2. Берәр нәрсәнең кыска гына гомуми тасвирламасы, аңлатмасы, сызмасы. *Пьесаның схемасы. Докладның схемасы.*

3. *күч.* Күп тапталган форма, әзер план; бик коры, җансыз тасвирлама. *Прокурорның --- басым ясавы „дәлилләрдән чыгып гаепне танырга" дигән схемага корылган иде.* Каз. утл. *Яңа җәмгыять кешеләрен күрсәтү, схемаларны түгел, ә реаль --- совет кешеләрен күрсәтү бурычы йөкләнгән [совет язучыларына].* Г. Иделле.

СХЕМАЛАШТЫРУ *ф. кит.* Бик гомуми төстә тасвирлап һәм гадиләштереп бирү. *Мәҗит Гафуриның бу әсәрдә биргән эшче сурәте — гомумиләштереп, схемалаштырып бирелгән сурәт.* Г. Нигъмәти. *Мәсьәләне [әдәби үсешне] артык гадиләштерү, схемалаштыру гына булыр иде бу.* Г. Халит.

СХЕМАТИЗМ *и. к.* схемачылык. [*Шагыйрьләрдә*] *схематизмга бирелү очраштыргалый.* М. Максуд. *Типны эшләүгә менә шулай коры схематизм, ясалма тенденция белән килү „әндәр карт"тагы төп иҗаби* [*уңай*] *геройны иң сәлби* [*кире*] *типка әйләндергән.* М. Җәлил.

СХЕМА¹ТИК *с. кит.* **1.** Схема (1 мәгъ.) рәвешендә бирелгән, күрсәтелгән. *Телеграф аппаратының схематик күренеше. Схематик карталар.*

2. *күч.* Бик гомуми сызыклар белән генә бирелгән; гадиләштерелгән. *Әдәби әсәрдәге схематик образлар.* □ *Автор тормыш вакыйгаларын сурәтләгәндә схематик, шаблон алымнардан ныклап сакланып эш итә һәм дөрес эшли.* Г. Иделле.

СХЕМАЧЫЛ *с. к.* схематик (2 мәгъ.). *Схемачыл алымнар. Схемачыл типлар.*

СХЕМАЧЫЛЫК *и. кит.* Тасвирлау-сурәтләүнең бик гомуми сызыклар белән һәм гадиләштереп бирелү күренеше. *„Безнең көннәр" кәгазларын шушы талләпләрдән килеп тикшерү әсәрдәге характерларның схемачылыктан азат булганлыгын --- күрсәтәчәк.* Г. Нигъмәти.

СХО¹ДКА *и. кит.* Октябрьга кадәрге Россиядә: эшчеләрнең, студентларның һ. б. революцион җыелышы. *Укырга кергәннең беренче елында ук аның* [*Ленинның*] *студентлар сходкасында катнашуы очраклы хәл түгел.* Г. Ахунов.

СХОЛАСТ *и. кит.* **1.** Схоластика (1 мәгъ.) тарафдары.

2. Схоластик рәвештә фикер йөртүче; формалист, хәреф ятлаучы. *Яз көне сазлыклардан чыккан бакалар иске мәдрәсәнең схоласт шәкертләрен* [*шагыйрьнең*] *исенә төшерәләр.* Г. Нигъмәти.

СХОЛА¹СТИК *с.* **1.** Схоластикага (1 мәгъ.) караган, шуңа мөнәсәбәтле. *Схоластик тема.*

2. Схоластикага (2 мәгъ.) нигезләнгән, тәжрибәгә таянмый торган; формаль. *Схоластик бәхәс. Схоластик укыту.* □ [*Галилей*] *урта гасыр схоластикасы кануннарын җимерде. Ул үзенең „Дөньяның иске төп системасы турында диалог" дигән хезмәтендә Коперник тәгълиматын тагын да үстерде, схоластик фикерләү методыннан көлде.* Соц. Тат. || Схоластика белән сугарылган. *Ул кадим фикерле муллаларны, иске схоластик мәдрәсәләрне, ишаннарны карый, зәкатен, сәдакасын шуларга гына бирә иде.* Г. Ибраһимов.

СХОЛА¹СТИКА *и.* **1.** Урта йөзләр философиясендә хакимлек иткән юнәлеш: ясалма, формаль логик дәлилләр ярдәмендә дин догмаларын теоретик яктан аңлатуны максат итеп куйган. *Иске мәдрәсәнең пычрак, караңгы, сасы, салкын бүлмәләре дә, гыйлем дип укыткан иске чүп-чар схоластикалары да --- косасыны китерү дәрәҗәсендә туйдырган иде инде.* Ш. Фидаи.

2. Тәжрибәгә таянмыйча, абстракт, формаль фикер йөртүләргә генә нигезләнгән, тормыштан аерылган гыйлем, тәгълимат; хәреф ятлаучылык. || *ирон.* Буш, мәгънәсез бәхәс.— *Д син дошманга качарга мөмкинлек биргән кешеләрне аклау өченме әллә схоластика корып маташасың?* Ш. Камал.

СЦЕНА¹РИЙ *и.* Кинофильм иҗат итү өчен махсус яраклаштырып язылган әдәби әсәр. *Сценарий язу. Киноның сценариен укып чыгу.* □ *Дөрес, бездә нәфис фильмнар куярлык зур студия дә юк. Әгәр яхшы сценарийлар яза алсак, шундый кешеләребез булса, шушы кечкенә студия белән дә кайбер эшләр башкарып булыр иде.* И. Гази.

СЦЕНАРИСТ *и.* Сценарий авторы. *Кеше, дөньясын оныты, кино карый. Кемнеңдер язмышы белән мавыга. Д бит ул язмыш әнә шул сценарист күңеленда туган.* Каз. утл.

СЧЁТ *и. махс.* **1.** Алган яки аласы товарның гомуми бәясен хисаплап күрсәткән рәсми кәгазь, язу; гомумән берәр нәрсә өчен түләнәсе суманы күрсәткән документ. *Күргәзмә әсбаплар кибетеннән счет алып кайту.* □ [*Банкрот булырга әзерләнүче сәүдәгәр бай:*] *Зурколаковка счет буенча бирәчәк — өч мең биш йөз сум.* Ш. Мөхәммәдев.

2. Төрле оешмаларның яки аерым кешеләрнең банк, саклык кассасы һ. б. ш. аркылы финанс операцияләре үткәрү хокукы; шул хокукны бирә, раслый торган документ. *Банкта счет ачу. Типография счетына акча күчерү. Саклык кассасындагы счетны ябу.*

СЧЁТЧИК *и. махс.* Саный, исәпли торган җайланма, аппарат. *Электр өчен ел ахырында счетчик буенча исәп-хисап ясау. Механик счетчик. Газ счетчигы.* □ *Сездән дүрт тәңкә дә җитмеш тиен!— диде таксист, счетчикка күрсәтеп.* В. Монасыйпов.

СЪЕЗД *и.* Оешмалардан, халык катлауларыннан килгән вәкилләрнең җизтимагый-политик, фәнни һ. б. мәсьәләләрне тикшереп хәл итә торган зур җыелышы. *Партия съезды. Укытучылар съездына делегат булып сайлану. Съезд ачылу.* □ *Вахитны шәһәрдә булачак съездга вәкил итеп җибәрделәр.* М. Гафури.

СЫБЫЗГЫ *и.* **1.** Эченнән һава өреп үткәргәндә сызгыру авазлары чыгара торган әйбер, җайланма, корал. *Таш сыбызгы. Аучы сыбызгысы.* □ *Милиционер сыбызгысын яман кычкырта башлады.* Ә. Еники.

2. Сыбызгыдан (1 мәгъ.) чыккан сызгыру тавышы. *Узыш ярышында беренче сыбызгыдан соң ук йөгереп киту. Сыбызгы ишетелү.*

3. *күч. сөйл.* Артык күп чәрелдәүче такылдык кеше турында. [*Фатыйма:*] *Күпме әйттем: ташла сәүдәңне, ташла сәүдәңне... Юк! Карун кебек һаман мал җыярга карадың.* [*Габдулла:*] *Тик тор, сыбызгы! Син нәрсә беләсең.* Һ. Такташ. [*Ферма мөдире — малайга:*] *Нәрсә дисең син, сыбызгы? Нинди тәртип кирәк тагы сиңа?* Г. Бакиров. || Булдыксыз, сәләтсез кеше турында.— *Бозма көйне, сыбызгы! Мыскыл итмә халык моңын!* Г. Бәширов.

СЫБЫЗГЫЧЫ *и.* Сыбызгы сызгыртучы. *Сыбызгычы малай.*

СЫГУ I *ф.* **1.** Кысып, эчендәге суын чыгару. *Мәдинә яңгырда чыланган җиң очларын сыгып алды.* К. Нәҗми.— [*Судан*] *чыккач, яр читендә ташка утырып, чәчемне сыга башладым.* Э. Касыймов. || Берәр нәрсәгә сеңгән, аның эчендәге яки составындагы сыек матдәне һ. б. кысып чыгару. *Кызарып та пешкән алманың Су гынасын сыгып шикәр ит.* Г. Тукай. *Усемлек майларын көнбагыш, җитен, киндер, соя һәм башка орлыклардан сыгып чыгаралар.* А. Расих. — *Кызлар, барыгыз инде, бар, тула суынмасын. Керен яхшылап сыга күрегез.* Т. Гыйззәт.

2. Юган әйберне борып, кысып, сеңгән суын агызып коруту. *Икесе дә кер чайкарга төшкән булалар. Һаҗәр шунда Хәерниса апаның керләрен алып бәләкли, чайкый, сыга.* С. Рафиков. [*Газизә*] *инде яулыкны сыгып маташа иде.* Ш. Камал. || Керне: тиз һәм җиңелчә генә юып алу. [*Тәскирә*] *су җылытырга, бераз гына керләр сыгып алырга дип, казан астына өстәп җибәрде.* Ф. Хөсни. *Хәерлебанат малайның күлмәк-ыштаннарын сыгып читәнгә элде.* А. Гыйләҗев.

3. *күч. сөйл.* Берәүдән берәр нәрсәне, бер дә калдырмыйча, бетергәнче (күп) алу. *Көчне сыгу.* □ *Киләдер күп кодалар, Обжор кебек тыгалар, Коданың хәлене белмиләр, Актык маен сыгалар.* Ш. Мөхәммәдев. [*Кавыштыручы карчык — бай турында:*] *Әй саран дуңгыз, нинди матурны китереп тә, бары утыз*

гына тәңкә биргән. Тагы кулга төшәр әле, ул вакытта ничек итеп сыгарга кирәклеген белермен. Г. Камал.

4. *күч.* Әдәби әсәрнең һ. б. язманың: әһәмиятсезрәк урыннарын төшереп калдырып, нык кыскарту. *Бу — язучының бер мемуары, --- әллә ничә төрле фактны бергә җыеп, сыгып, кысып чыгарылган бер хатирәсе.* Г. Газиз.

СЫГУ II *ф.* **1.** Элекке торышына кире кайта торган, сыгылмалы нәрсәләрне: бөгү. *Ботакны сыгып алма өзеп алу.* □ *Тәлгәшләрен күр син виноградның, Куакларын сыгып төшкәннәр.* Г. Хуҗи. *Камали, түшәм такталарын сыгып, өскә балчык коеп чормада йөри.* К. Нәҗми.

2. *күч.* Бик ардыру, хәлсезләндерү, изү. *Авыр, киренкә эш, тузан-туфрак һәм черки — барысы бергә җыелып Вагыйзне бөгә, сыга башлады шикелле.* Н. Фәттах. *Сыкмакчы була дөнья, [ләкин] сыгылмыйм! — дигән сымак итеп, иңбашын киереп, сынын турайтып куйды [Фәсхи].* Ф. Хөсни. || Бөлдерү. *Революциягә хәтле ул кызыл мал белән нык кына сәүдә иткән дә, революция еллары аны сыктылар, ул сумасызланды.* Г. Толымбай.

СЫГЫЛДЫРУ *ф. к.* сыгу II (1 мәгъ.). *Агач ботагын сыгылдыру.* □ *Әнә нинди алмалар, нинди чияләр, агачларын сыгылдырып, салынып тораларl* Г. Бәширов. *Сыгылдырып күл камышын, җилләр исә.* Дәрдмәнд. *[Биюче егет] ике кулын җәеп, гәүдәсен әрле-бирле сыгылдырып, аякларын җиргә ныклап тибеп, түгәрәкне әйләнеп йөри башлады.* М. Гафури.

СЫГЫЛМА *и.* Сыгылу, бөгелү хәрәкәте; сыгылу хәле. *Ул биюнең техникасын, бөгелмәләрен-сыгылмаларын --- барысын да белә иде.* Ф. Хөсни.

СЫГЫЛМА, СЫГЫЛМАЛЫ *с.* **1.** Сыгыла, бөгелә торган. *Сыгылмалы агач. Сыгылмалы басма. Сыгылма такта.* □ *Кечкенә бүлмәсендәге сыгылмалы караватта Сәҗидәкәй тәмле иттереп йоклый.* Г. Иделле. *Үгездәй таза ике әсәсчы, җиңнәрен сызганып, кулларына озын сыгылма чыбыклар тотып, комендантның боерыгын көтәләр.* Г. Әпсәләмов.

2. Матур, нәфис, җиңел хәрәкәтле (гәүдә һәм әгъзалар турында). *Сыгылма гәүдәле кеше.* □ *Юк, юк, җилбәзәкләнеп, кыланып түгел, үзенең сыгылмалы билләренең, калку күкрәкләренең бәясен, дәрәҗәсен белеп кенә бии ул.* А. Гыйләҗев. *Малайларга хас сыгылмалы гәүдәләрен уйнатып, дүрт бырчы бырчы уйнарга әзерләнәләр.* Г. Ахунов. || Кискен түгел, матур һәм җиңел (тән хәрәкәте һ. б. ш. турында). *[Кыздагы] матур тулы беләкләрнең елгырлыгын, көчле сынның сыгылмалы хәрәкәтләрен Нәдерша, беренче күргәндәй, сокланып күзәтте.* И. Туктар. || Җиңел гәүдәле, матур һәм җитез хәрәкәтле (кеше турында). *Дхтәри белән көрәшүче ябык, әмма сыгылмалы Тимри, тегене җирдә калдырып, үзе сикереп торды.* Ә. Фәйзи.

3. *күч.* Күп шартларга, очракларга яраша, кешеләргә җайлаша белә торган. *Фәсхи башта Тимерне сугыш коммунизмы каһарманы, ул бу көн дә шул юл белән бара, сыгылмалы түгел дип уйлаган иде.* Ф. Сәйфи-Казанлы. *Кеше акылы бик нечкә һәм сыгылмалы.* М. Җәлил. || Күп шартларны, очракларны исәпкә ала, җайлашырга мөмкинлек бирә торган (чаралар, политик алымнар һ. б. ш. турында). *Мондый шартларда тәмам һәлакәткә очрамас өчен, нинди дер сыгылма чаралар күрергә, мин-минлекне авызлыкларга кирәк иде.* Г. Әпсәләмов.

СЫГЫЛМАЛЫЛЫК *и.* Сыгылмалы булу сыйфаты һәм хәле. *Организм тышкы тирәлекнең катлаулы, үзгәрүчән --- шартларына яраклашуда сыгылмалылыкны акрынлап югалта.* Соц. Тат.

СЫГЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сыгу II.

2. Бөгелү (элекке торышына кире кайта торган эйберләр турында). *Сыгыласың, гөл, бөгеләсең, Чәчкәң авыр, күрәсең?* Х. Туфан.— *Сыерлар абзарының өрлеге сыгылган, әчтән берәр терәү кисәге салырсың.* Т. Гыйззәт. *Шүрлекләр сыгылырлык булып товар белән тулган.* Г. Минский.

3. Иелү, бөгелү. *Мостафа абый, улларын тотып тора алмыйча, сыгыла башлаган иде, Илдар, сизенеп, кулларын аның муеныннан алды.* Г. Гобәй. *[Әби], баскан җиреннән сыгылып төшеп, камыш намазлык өстенә утырды.* М. Гали.

4. *күч.* Авырлыкларга түзмәү, бирешү. *Зөһрә апа кайгыны йота белде, нужага сыгылмады.* Ә. Фәйзи. *Беренче балалары үлде, ире сугыштан кайтмады, берсеннән-берсе кечкенә ике бала белән тол калды, йорты янды... Хатын-кыз кешегә сыгылып төшәр өчен азмыни болар?* Г. Әпсәләмов.

СЫГЫЛЫШ *и.* **1.** *сир.* Сыгылу (1—3 мәгъ.) хәрәкәте, хәле һәм рәвеше. *Сыгылышның бик әз генә, кечкенә генә булуы. Тиз сыгылышлы чыбык яки такта.* □ *Мин аның саба җиле белән җиңелчә генә алга сыгылган яшь, туры тубылгы чыбыгы шикелле матур буеның матур сыгылышына --- мәхәббәт белән карап килдем.* Ф. Әмирхан.

2. *күч.* Үзенне тотуның, мөнәсәбәтне үзгәртүнең, сүзне боруның алымнары һ. б. ш. турында. *Сөйлгәндә дипломатик сыгылышларны белми торган есаул турыдан сиптерә.* Ф. Хөсни.

СЫГЫНТЫ *и.* Берәр азыкны сыгып әзерләнгән сыек ашамлык.— *Нәрсә белән дәваладым? Җылы ванна. Аш юлын йомшарта торган дарулар. Сыек аш. Кишер сыгынтысы.* Г. Кутуй.

СЫГЫНУ *ф. к.* сыену. *Давыллы көннәрдә шунда барып сыгынган балыкчыларга әллә ничәшәр көн ач торырга туры килгәләгәнгә, ул атауны Ачлык атавы дигәннәр.* С. Җәләл. *Һушы китә язган Мәрьям, ярдәм өмет итеп, картына сыгынырга тора иде.* Ш. Камал.

СЫДЫРТУ *ф.* **1.** Берәр җиргә орындырып, ышкытып тырнату; җиңелчә суйдыру.— *Көтүченең әйтүенә караганда, [үгез] күпер ярыгына батып [аягын] сыдырткан.* Т. Гыйззәт. *Якупның капкасы бикле иде. Хәлим, аркасын сыдыртып, капка астыннан килеп керде.* И. Гази. *[Хуҗа хатын — пианиноны урынынан күчерүчеләргә:] Ай, идәнне сыдыртмасагыз иде.* Х. Вахит.

2. *күч. сөйл.* Тиз генә чыгып китү, чыгып югалу. *[Малайлар] кайсы кая качуны яхшырак санадылар. Зиннәт тә бик тиз генә урамга сыдыртты.* А. Шамов.

СЫДЫРУ *ф.* **1.** Нык ышкылып, тырнау; ышкылган җирдә эз калдыру. *Ишек алдына, киң бортлары белән капка баганаларын сыдырып, зур грузовик килеп керде.* Г. Гобәй. *[Ат] аның аягына басып, тиресен сыдырып алган.* Ә. Айдар. *Юл буендагы агач ботаклары янга таккан атымны сыдырып, тырнап калалар.* Ш. Әхмәдиев. || Ирексездән сыдырырга мөмкинлек бирү, шуңа юл кую; сыдырту. *Чытырманлыктан үткәндә кулларны, аякларны сыдырып бетерү.* □ *Билетка акча түләмәс өчен койма ярыкларына корсакларын сыдырып эчкә үткән әрсез малайлар арзанлы каруселдә әйләнәләр.* К. Нәҗми.

2. Каурыйны, яшь чыбыкны һ. б. ш. нәрсәне: ике бармак арасына яки учка кысып үткәреп, йон бөртекләреннән, яфрак, бөре, вак ботаклардан чистарту. *Каз суйган көнне канат сыдыру.* || Үсемлек сабагындагы вак тармакларны, яфракларны, җимешләрне, каурыйдагы йоннарны һ. б. ш. нәрсәне: шул рәвешле сыпырып

төшерү, алу, җыю. *Уңган елларны шомыртны-чиклә-векне сыдырып кына җыю.* □ [*Тал чыбыгының*] *яфракларын сыдырып, сөкә үрәбез.* Ш. Маннур. [*Ачлык елны*] *читән буйларыннан алабута орлыкларын сыдырып йөрүче ике хатынга күзем төште...* М. Әмир.

3. *күч. сөйл.* Тоташтан һәм җитез эшләп бетереп бару (эшне). *Бөтен өй эшен сыдырып эшләүче килен. Кушкан бер эшне сыдырып кына тору.*

4. *күч. сөйл.* Талымсызланып һәм рәттән-тоташтан барысын да ашау. *Тамак бик ачканда ни әләксә шуны сыдырып кую.* □ *— Ни ашыйсың син, малай, Каюм? Өйрәт әле шул сереңне! Минем менә эч эчкә ябышкан. Бер атна буе утыруда чиле-пешле ун йомырка сыдырып карадым. Корсак үсми генә бит.* Каз. утл.

5. *күч.* Гадәттә озынча әз калырлык итеп сугу (чыбык, чыбыркы кебек нәрсә белән). *Атка камчы белән сыдырып алу.* □ *Беркөн киртә өстенә менгән өчен дә аркасына чыбык белән сыдырды* [*Хәлимнең анасы*]. И. Гази. *Аның уң күзен алпавыт --- чыбыркы белән сыдырып чыгарган.* Каз. утл.

6. Сызганган кебек итеп җыерып китерү (җиңне, балакны һ. б. ш.). *Җиңне сыдырып кую.*

СЫДЫРЫЛУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сыдыру (1, 2, 5, 6 мәгъ.). || *Кайт. юн. к.* сыдыру (1, 5 мәгъ.). || Нык ышкылып, тырналу, кырылу. *Аның сул күзенең өсте маңгай аркылы кыйгачлап сыдырылган һәм канланып, кара көеп тора иде.* Ә. Фәйзи. [*Таудан егылганда*] *күзләремә туфраклар тулып бетте, аяк-кулларым сыдырылып эштән чыкты.* Ш. Камал. || Нык ышкылып, тырнау. *Аркылы-торкылы үскән куаклар юлыбызны киртәлиләр, сыдырылалар, битләребезгә, кулларыбызга килеп бәрелеп, өздереп алалар иде.* А. Шамов.

2. Җыерылып күтәрелү (балак, җиң турында) яки шуып төшү (оек һ. б. ш. турында). *Җиң сыдырылу. Балак сыдырылу.* □ [*Малайның*] *бер оегы резинка тасма белән тоттырылган, икенчесе ботинкасына кадәр сыдырылып төшкән иде.* А. Расих.

СЫЕГАЮ *ф.* **1.** Сыек (1, 2 мәгъ.) хәлгә килү. *Кара сыегаю.*

2. Тыгызлыгы, куелыгы кимү, сирәкләнү (томан, болыт, төтен, пар һ. б. ш. турында). *Төтен тора-бара ерагайды, кечерәйде, сыегайды һәм бөтенләй югалды.* Г. Гобәй. *Куе томан, таң атуын белдереп, сыегая, сөт төсенә керә бара.* Ә. Маликов.

3. Кимү, бераз ачылу, тоныклану (төсләр, караңгылык һ. б. ш. турында). *Караңгылык тагын бераз сыегая.* Г. Ибраһимов. *Вагоннар бер-берсе белән кушылып бик кызу алга шуган тоташ бер кызыл стена булып күренә башлыйлар. --- Ахырдан бу кызыллык сыегаеп чуар бер шәүлә әйләнә.* Ә. Еники. [*Кояш чыкканда*] *кызыл, ал, зәңгәр төсләрнең әле куера, әле сыегая барып чагылып-аралашып китүе --- гаҗәеп бер манзара иде.* Г. Иделле.

4. *күч.* Әзәю, җитми башлау (азык, акча һ. б. ш. турында).

5. *күч.* Сирәкләнү, әзәю, кимү. [*Галимҗан Ибраһимов*] *мин күз алдыма китергәннән кечерәк, ябыграк, чәче дә сыегайган, яңаклары да эчкә баткан иде.* Ф. Хөсни. *Кибеттә кеше сыегаеп, әни белән күршеләрчә саулык-сәламәтлек сорашкач, ул* [*кибетче*] *әнигә саусызлыгына зарланды.* М. Рафиков.

СЫЕК *с.* **1.** Агу, агып китү (чыгу) үзлегенә ия булган; сыеклык хәлендәге. *Сыек матдә.*

2. Куелыгы яки катылыгы җитәрлек булмаган; суы күбрәк булган. *Сыек аш. Сыек кара белән язу. Чәйне сыек итеп ясау. Асфальтсыз юлдагы сыек бикырдык.* □ *Бүген балык та шактый мул пешкән, башка көнге кебек сыек өйрә генә булмыйча, ике табакта бутка кебек өелгән килеш өстәлнең ике башына куелган.* Ш. Камал. || Сыекландырылган; куе түгел. [*Бай үзенең көтүчеләренә*] *күгәргән икмәк сыныклары белән өстен алган зәңгәр сөт я сыек әйрән эчереп җибәрә.* М. Гали.

3. Тыгыз түгел, сирәк (томан, болыт, төтен, пар һ. б. ш. турында). *Сыек пар. Сыек болыт.* □ *Күлдән сыек кына ак томан һавага җәелә.* Г. Ибраһимов. *Өйдән күккә сыек кына төтен күтәрелеп калды.* Ә. Фәйзи. || Махсус сирәкләтелгән. *Сыек газ.*

4. Тонык; көчле түгел (яктылык-караңгылык, төрле күренешләр турында). [*Сукачылар*] *басу капкасыннан чыгып, атларын чыбыркы белән кызулап сыек караңгылык эченә кереп югала бардылар.* И. Гази. *Таң яктысы бик сыек иде әле, шуңа күрә алар килүчеләрне таный алмыйча тордылар.* Г. Минский. || Төсне атый торган сыйфатлар алдында килеп, ул төснең кимлеген, тоныграк булуын белдерә. *Сыек яшел төстәге яшь үренте.* □ *Конвертлары гел бер төсле: Сыек зәңгәр буяулы.* М. Җәлил. [*Наташа*] *аппак битле, сыек сары чәчле.* Ш. Маннур.

5. Сыгыла торган, сыгылмалы. *Сыек чыбык.* □ *Идәннең сыек такталары сыгылалар һәм баскан саен шыгырдыйлар иде.* А. Расих.

6. Сирәк үскән яки урнашкан; еш түгел, куе түгел. *Җирән колын, алгы аякларын аерып, сыек яллы күк биянең яктавына борынын төртте.* К. Нәҗми. *Яңакларымның алсулыгы аз, чәчем сыек, буем кыска... дип бер вакытта да үз-үзеннән канәгатьсезләнеп зарланмады* [*Зөлфия*]. Г. Әпсәләмов.

7. *күч.* Көчсез, хәлсез, зәгыйфь (мускул, гәүдә, кеше һ. б. турында). *Сыек гәүдәле малай.* □ *Батыршиннар нәселе сәламәтлек җәһәтеннән буын-буыннан шулай сыеграк, куәтсезрәк булган.* М. Рафиков. [*Турникта*] *бердән ары күтәрелә алмый ул. Мускуллары сыек.* Ә. Маликов. *Кечерәк шул әле ул, буыннары сыеграк.* М. Шабай. || *күч.* Авырлык-кыенлыкларга түзми тиз бирешүчән; ихтыярсыз, җебегән. *— Хатын-кыз шикелле балавыз сыгып төн буе йокы бирмәдең: пленда алай сыек булырга ярамый.* Ш. Маннур. *Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, укырына да керә алмады бит ичмаса. Укыса, кеше булыр иде, дип уйлап куйды* [*анасы*]. *Улының шулай бераз сыеграк булуын ул бары тик карт иреннән генә күрде.* М. Хәсәнов.

8. *күч.* Көчсез, зәгыйфь чыга торган (аваз турында). [*Гаепләнүче*] *сыек тавыш белән җавап кайтарды.* Г. Ибраһимов.

9. *күч.* Мул түгел, җитәрлек түгел, әз. *Сыек алкышлар.* □ *Сый сыек булды. Берәр кружка суынган чәй — бар хөрмәт.* Каз. утл. || Ким, үсеп җитлекмәгән; кимчелекле (акыл, сәләт һ. б. турында). *Белем сыек булу.* □ *Күп мәгънә юк үстерүдә сакал-мыек, Башында булса әгәр акыл сыек.* Г. Камал.

10. *күч.* Әһәмиятсез яки кирәксез сүзләре, җөмләләре күп, ә кыйммәте түбән (әсәр, доклад, төрле язмалар, аларның эчтәлеге һ. б. ш. турында). *Сыек эчтәлекле мәкалә.* □ *Петроград телеграф агентствосының хәбәрләре бик сыек иде.* Ш. Камал.

СЫЕКЛАГЫЧ *и.* Сыеклау өчен кулланыла торган нәрсә. *Эч сыеклагыч дару.* □ *Җир атмосферасы күләменең 78 процентын тәшкил итә торган азот „кислород сыеклагыч“ кына булып кала алмый, бәлки тере организмга җитди биологик тәэсир дә ясый.* Соц. Тат.

СЫЕКЛАНДЫРУ *ф. к.* сыеклау. *Карага самовардан чак кына су җибәреп сыекландыру.* □ *Миңлебай газ-бензин заводында --- нефть белән ияреп чыга торган газны промыселлардан кабул итеп алалар да сыекландыралар.* Каз. утл.

СЫЕКЛАНУ *ф.* **1.** Сыек (1, 2 мәгъ.) хәлгә килү.

2. Тыгызлыгы, куелыгы кимү, сирәкләнү (томан, болыт, төтен, пар һ. б. ш. турында). *Томан сыекланып югала башлады.* Г. Кутуй.

3. Тоныклану, ачыклыгы кимү (яктылык-карангылык, төсләр, күренешләр турында). *Таң сызылды. Күк чите агарынып, төн караңгысы сыеклана башлады.* Ш. Усманов. [*Мәдинәнең*] *уйлануларында шәһәр белән Фәтхи гел икәвесе бергә чагыла һәм актыгында шәһәрнең чагылышы бөтенләй сыекланып, Фәтхи үзе генә диярлек Мәдинәнең хыялында каладыр иде.* Ш. Камал.

4. Тиз сыгылучан хәлгә килү (чыбык һ. б. ш. турында).

5. *күч.* Көчсезләнү, хәлсезләнү, зәгыйфьләнү (мускул, гәүдә, кеше һ. б. ш. турында).

6. *күч.* Азаю, житми башлау. *Менә шушындыйрак чакларда, яшерен чир төсле, яңадан бәреп чыга инде ул* [*искелек*]. *Бигрәк тә Бикбулат шикелле акылы сыеклана башлаган борынгы картларда.* Г. Бәширов. || Кимү, азаю, жинеләю (эш һ. б. ш. турында).— *Һидият әйтә, юк кына әйбергә чакыралардыр, бармыйк, ди. Эш сыеклана төшкәч барырбыз, янәсе.* Ш. Камал.

СЫЕКЛАТУ *ф. к.* сыеклау. *Зур савыт белән әче әйрән сыеклатып эчтем.* Г. Ибраһимов.

СЫЕКЛАУ *ф.* Берәр сыек нәрсә, мәсәлән су кушып, катнаштырып сыек (1, 2 мәгъ.) хәлгә китерү. *Ацетон кушып буяуны сыеклау. Из әне сыеклау.* || Сыеклык хәленә китерү. *Газны сыеклау.*

СЫЕКЛЫК *и.* **1.** Ага торган һәм үзе салынган савыт формасына керә торган матдә.

2. Сыек булу хәле, рәвеше. *Буяуның сыеклык дәрәҗәсен билгеләү.*

СЫЕКЧА *и.* Сыек матдә, сыеклык. *Җирән солдат кулындагы ярты литрлар чамасы (бензинмы, керосинмы) сыекчаны салам өстенә сипте һәм шырпы кабызып ут төртте.* Ф. Кәрим. *Авыз эчендә бизләр бар. Алар азык чылату өчен сыекча бүлеп чыгаралар.* А. Расих.

СЫЕКЧАЛЫ *с.* Эчендә сыекчасы булган яки сыекча салынган. *Бүген без ул кадәр курыкмыйбыз, чөнки тау алдыннан майор Ильин безгә күп итеп гранаталар һәм сыекчалы бутылкалар китереп өлгерде.* И. Гази.

СЫЕНДЫРУ *ф.* Сыенырга мөмкинлек бирү. *Баланы үзеңә сыендыру.* || Сыенырга рөхсәт һәм урын бирү. *Эзәрлекләнүче чит ил гражданнарын сыендыру.*

СЫЕНУ *ф.* **1.** Яклау эзләп яки иркәләнеп берәүнең янына килү, аны кочаклау, кочагына керү һ. б. ш. *Кочакка сыену. Ана куенына сыену.* □ *Аяк астында, Зиннәткә сыенып китә-китә, мәче мыраулап йөри.* А. Шамов. *Хәлим, жылы тун эченә сыенып, атасын тыңлап утырырга ярата.* И. Гази. *Бала, Зарифка сыена төшеп, бер кулы белән аның муеныннан урап алды.* Ә. Еники. || Берәр жиргә яшеренү, посу, ышыклану. *Алар чатыр эченә сыенып яңгыр туктаганны көтә иделәр.* Ш. Камал. *Камышлар арасына балыклар сыена.* З. Бәшири.

2. Ярдәм итәрдәй берәр кеше янына, иминлекне тәэмин итәрдәй берәр жиргә: урнашу. *Безнең Фазыйл да үзенең Мәскәүдәге дуслары, байлары аркасында шунда* [*жиңел эшкә*] *барып сыенган ди.* Г. Ибраһимов.

СЫЕНЫЧ *и.* Сыендырырдай, сыенырга (2 мәгъ.) мөмкин булган кеше яки урын. [*Хөсрәү*] *Иран бәкләренең иде сыенычы, Гаскәрләрнең байрагы һәм канкылычы.* Н. Исәнбәт.

СЫЕР *и.* Сөт өчен асрала торган мөгезле эре терлек. *Савым сыер. Сөзгәк сыер. Сыер ите. Сыер лбзары. Сыерны көтүгә куу.* □ *Сыерның сөте тегаендә.* Мәкаль.— *Хәзер сыер бозауламаган әле, сөткатык юк.* М. Гали. || Бүтән кайбер эре мөгезлеләрдә ана хайван. *Поши сыеры. Болан сыеры.*

СЫЕРУ *ф.* Сызганган кебек итеп жыеру (жиңне, балакны һ. б.) яки сыдырып күтәрү, ачу (итәкне, чаршауны, тәрәзә пәрдәсен һ. б.). *Сай елганы кичкәндә балакны сызганып тормыйча, сыерып кына кую. Врач күкрәкне тыңлаганда, күлмәкне сыерып күтәреп тору.* □ *Ул брезент ишекне сыерып ачты да палаткага кереп китте.* Х. Камалов.

СЫЕРЧЫК *и.* Гадәттә йорт тирәсендә оялый торган, чыпчыктан эрерәк, кара каурыйлы күчмә сайрар кош. *Сыерчыклар килде ераклардан, Канатында безгә яз алып.* С. Урайский. *Колга башына куйган сыерчык оясында сыерчыкның бик ләтафәт белән сайравы Галим хажига рәхәтлек бирә иде.* Г. Газиз.

СЫЕРЫЛУ *ф. Төш. юн. к.* сыеру. || Жыерылып күтәрелү (балак, жиң һ. б.) яки шуып төшү (оек һ. б. ш. турында). *Ул бер аягын тартып чыгарды, ләкин обмотка* [*чолгау*] *сыерылып балчык эчендә калган иде.* Х. Камалов.

СЫЕШЛЫ *с.* **1.** Сыйдырырлык; билгеле бер микъдар-күләмле нәрсә сыярлык. *Мең баш терлек сыешлы ферма. Бер пот сыешлы капчык.* □ *— Кем соң бездә азык чөгендере чәчүне башлап кертте, кем илле тонна сыешлы тагын бер силос базы казытты?* Ә. Еники. *Берничә рәт ике чиләк сыешлы самовар кайнатылды.* М. Гафури.

2. Берәр жиргә сыярлык, сыярдай. *Кесәгә сыешлы китап форматы.*

СЫЕШЛЫК *и.* Сыю-сыйдыру күләме. *Мичкәнең сыешлыгын билгеләү. Электр үткәргечнең сыешлыгы.*

СЫЕШМАУ *ф.* **1.** Сыймау, сыя алмау (ишле төркем, берәр абстракт күренеш һ. б. турында). *Киң Иделнең ярларына Сыеша алмый ага боз.* М. Җәлил. *Шатлык ярсуының дулкыннары Сыеша алмый минем күңелгә.* Ф. Кәрим.

2. *күч.* Килешеп, тынышып тора алмау, тату булмау.— *Сыешып тора алмам мин Дәүләтъяров белән.* И. Гази. *Монда Чуракай баскакны хурлап жыр әйткән ич* [*чичән*]. *Шуннан сыеша алмый киткән дә.* Н. Исәнбәт.

3. Ярашмау, бер-берсенә каршы килү (карашлар, принциплар һ. б. ш. турында). *Аерым төркемнәрнең фикере шактый аерылырга, хәтта бер-берсе белән сыешмаска да мөмкин.* А. Тимергалин.

СЫЗА *и.* Коры елга. *Исәпсез-хисапсыз инеш һәм сызалар, эре һәм вак елгалардан шаулап агып килгән язгы кар сулары белән тулган Идел* [*кузгала*]. С. Сабиров.

СЫЗГАЛАУ *ф.* **1.** *Каб. дәр. к.* сызу I.

2. Язу, рәсем ясауны һ. б. ш. тиз-тиз, өстән-өстән генә башкару. *Сәяхәт вакытында куен дәфтәренә шигырьләр сызгалау.* □ *Якты беткәнче языйм дим, сызгалыйм тиз-тиз генә.* Г. Тукай. *Күзләремне ала алмыйча озак кына аңа карап тордым һәм шунда ук альбомга рәсемен дә сызгалый башладым.* С. Сабиров. [*Тикшерүчегә жавап бирүче карт:*] *Гыймадиның сүзләрен язып дөнья тутыргансың! Минекен иренеп, аннан-моннан гына сызгалап утырасың!* Г. Ибраһимов.

СЫЗГАНУ *ф.* **1.** Эш-хәрәкәткә комачауламасын өчен кайтарып күтәреп кую (жиңне, балакны). *Чалбар балакларын тезгә хәтле сызгану. Кер юганда жиңне сызгану.* □ *Көймә кире әйләнеп килгәндә Илдар, чалбарын сызганып, бот төбеннән суда басып тора иде.* Г. Гобәй. || Эш-хәрәкәткә комачауламасын өчен жиңен, балагын кайтарып күтәреп кую (кулның, аякның). *Кичүдән аякны сызганып чыгу.* □ *Гафият*

абзагыз да бүген иртәдән бирле кырда эшли: беләкләрен сызганган, маңгаеннан гөрләп тир ага. И. Гази. *Яңа эшләр, яңа көрәшләргә Кул сызганыйк тагын, иптәшләр!* М. Җәлил.

2. *рәв. мәгъ.* **сызганып.** Бик тырышып, бар көчең белән (эшләү турында). *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә.* Г. Тукай. *Мин үзем әле карт булсам да, сызганып торып Советка хезмәт итәм.* Һ. Такташ.

СЫЗГАНУЛЫ *с.* Сызганган, сызганып куелган (җиң-балак, балтыр-беләк турында). *Сызганулы балак белән кармак салып йөрү. Сызганулы беләк.* □ [*Врач*] *битенә марля каплаган, халат өстенә полиэтилен алъяпкыч япкан, җиңнәре сызганулы.* Каз. утл.

СЫЗГЫ *и.* Балта эшендә, столярларда: юну сызыгын билгеләү (сызу) коралы.

СЫЗГЫРТКЫЧ *и.* Сызгырта торган нәрсә; сыбызгы. *Паровоз сызгырткычы.*

СЫЗГЫРТУ *ф.* 1. Сыбызгы һ. б. ш. нәрсә ярдәмендә сызгыру авазы чыгару. *Кинәт урам ягында кемнеңдер кычкыру тавышы, соңыннан милиционерның сыбызгы сызгыртуы ишетелә.* Һ. Такташ. *Вәли абзый да базардан кайтып керде һәм авызына капкан калай этәчне сызгыртып* [*күрсәтте*]. Ә. Фәйзи.

2. Сызгыруга охшаш тавыш белән кычкыртып, сигнал бирү (пароход, завод һ. б. ш. турында). *Якынлаша төшкәч пароход тагы сызгыртты; сызгыртты да үзе дулкыннар эченнән шаулатып, салны бер як ярга таба кысып, утеп китте.* Г. Ибраһимов. *Әнә әллә кайдан бер фабрика моңлы гына, киң генә тавыш белән озак, сузып сызгыртты.* Ф. Әмирхан.

3. Туң майны ашка кыздырып салу турында.

СЫЗГЫРУ *ф.* 1. Һава агымын бөрелгән ирен яки кысылган теш яисә сыбызгы һ. б. аркылы көч белән үткәреп (өреп яки суырып) нечкә ачы-кискен аваз чыгару. *Хәлил ике бармагын авызына кабып әче итеп сызгыра.* М. Фәйзи.— *Сыбызгыны мин сәрви агачы кузагыннан ясыйм. Бик шәп сызгыра.* А. Әхмәт.

2. Сызгыруга охшаш тавыш чыгару: кычкыру (кайбер җәнлекләр), ысылдау (еланнар), сайрау (кайбер кошлар турында) һ. б. ш. *Йомран сызгыру.* □ *Баскан әз дә куркыныч, уклы еланнар сызгыра.* Һ. Такташ. *Кошлар пырхылдап очарга, төрле көйгә көйләргә, сайрарга, сызгырырга тотындылар.* Г. Минский. *Үлән арасындагы чикерткәләрнең дә сызгыруы сүлпәнәйгән — ул тынгысыз җан ияләрен дә әкрен-әкрен йокы баса, күрәсең.* Э. Касыймов.

3. Сызгыруга охшаш тавыш белән чыжлау, ыжгыру (җил яки зур тизлек белән һава ярып үтүче нәрсәләр һ. б. турында). *Җил сызгыру. Селтәгән чыбыкның һава ярып сызгыруы. Снарядның баш очыннан сызгырып үтүе.* □ *Сары самовар, чәйнеген кырын салып, күңелле сызгырып буш табында утыра.* И. Гази.

4. Сызгырып көй чыгару; сүзсез җырлау. [*Газиз*] *бер моңлы гына көй сызгырырга тотына.* Ф. Әмирхан. *Ул аннан, ниндидер матур, дәртле бер көйне авыз эченнән сызгыра-сызгыра, күтәренке күңел белән кайтып килде.* А. Шамов.

5. Сызгырып чакыру яки хәбәр бирү. *Күрсәм сине, сызгырырмын, артыңа әйләнеп кара.* Г. Тукай. *Билемдәге ал билбавым Тормый кыстырган җирдә; Үзе чакыра, үзе кача, --- чыкмый сызгырган җиргә.* М. Фәйзи. || Сызгырып, кузгалырга кушу, әйдәү яки эчәргә кыстау (атны һ. б. хайванны). *Атны әйдәп сызгыру.* □ *Тигәнә тирәсендә байтак маллар бар, бер егет шуларны эчәргә кыстап, сызгырып тора.* Г. Ибраһимов.

6. Сызгырып, гаҗәпләнү, соклану һ. б. хисне белдерү. *Маврның чит илдә һәм моннан бик күп еллар элек яшәгәнлеген белгәч,* [*Газинур*] *сызгырып җибәрде.* Г. Әпсәләмов. || Сызгырып, берәр нәрсәне ошатмау, шелтәләү, хурлауны белдерү. [*Көлкегә калган Мәрьямнең*] *артыннан берничә кеше тагын да кычкырып, сызгырып маташтылар.* Ш. Камал. *Шәкертләр беренче мәҗлестә аптырап карадылар, икенчесендә аңа каршы бәйләнеп чыктылар, өченче җыелышта сызгырып, кычкырып, сүзен бүлдерделәр.* Г. Ибраһимов.

7. *күч.* Зур мохтаҗлык кичерү. *Нәкъ шуның күк бер заманны дөньясын типкән халык Инде алҗып тик йөридер, сызгырып, ай-һай салып!* Ш. Бабич.

СЫЗГЫРЫК *и. диал.* Сызгыру авазы. *Шайтани бер сызгырык булганга бу, Шундук ишетелде бөтен шайтанга бу.* Ш. Бабич.

СЫЗГЫРЫНУ *ф.* Үз алдына сызгыру. *Алгы терасага кулына китап тотып Габдулла чыга да сызгырынып басып тора башлый.* Ф. Әмирхан.

СЫЗГЫЧ I *и.* Шырпы кабында: шырпыны сызып кабызу өчен махсус матдә ябыштырылган өслек, ян.

СЫЗГЫЧ II *и.* Уен коралының кылларына сызып уйнау өчен ат кыллары тарттырып ясалган таякчык; *русчасы:* смычок. *Габдулла скрипкәне нәкъ Фәскый кебек итеп күкрәгенә тери дә сызгычны кыллар өстенә салып сызып җибәрә.* Ә. Фәйзи.

СЫЗГЫЧ III *и.* Туры сызу өчен хезмәт итә торган тигез кырлы юка тактачык; линейка. *Класс шунда ук тынып кала, балаларның тын алулары гына ишетелеп тора. Бу Муратовка* [*урядник малаена*] *ошамый; ул, дүрт кырлы сызгыч алып, һәркайсыбызның башына сугып чыга.* Ш. Мөдәррис.

СЫЗДЫЙ-БЫЗДЫЙ, СЫЗДЫ-БЫЗДЫ *с.* Начар башкарылган, биек ямьсез (язу, рәсем, бизәк, буяу һ. б. турында). [*Йортын яратмаучы хатын:*] *Идән буяулары сыздый-быздый.* Г. Зәйнашева. *Ул яхшы гына рәсем төшерә иде. Минем сызды-бызды рәсемнәремне тикшереп, киңәш бирә иде.* Каз. утл.

СЫЗДЫРТУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* сызу I (1—9 мәгъ.).

2. Чыбыркы, чыбык һ. б. ш. нәрсә белән сугу. *Кучер атларына берне сыздыртып алды.* Х. Кәрим. *— На, хайван, вагонга мен! — Камчы белән сыздырт, камчы белән!* Ш. Усманов.

3. Сыдыру, тырнату. *Габиш берни белми тәмле итеп йоклый. Теге малай идәннән кулына бер салам кисәге алды да шуның белән Габишнең битен сыздыртты.* Ф. Кәрим.

4. *күч.* Бик оста җырлау, уен коралын уйнау, сайрау һ. б. ш.— *Әйдә сыздырт гармунны!* М. Максуд.

5. *күч. сөйл.* Качып яки куылып: китү. *Мин түзә алмадым. Йодрыкларымны йомарлап, аңа таба атладым.— Әһә-ә! --- Сыздырт бакчадан! Югыйсә, күрәсеңме моны.* Г. Мөхәммәтшин. *Өстәл өстендә суынырга өлгермәгән аш тора. Өстәл янындагы урындыкта немец генералының мундиры ята. --- Күрәсең, немец генералы ач-ялангач сыздырткан!* Г. Кутуй.

СЫЗДЫРУ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* сызу I. || Сызарга (I) мөмкинлек бирү, рөхсәт итү.

2. Чыбыркы, чыбык һ. б. ш. нәрсә белән: сугу. *Минем дә әллә нәрсәгә ачу чыгып кайткан чак иде. — Ни юкны сөйлисең, малай актыгы! — дип сыздыр моның җилкәсенә берне дилбегә белән.* Ә. Камал.

3. *күч.* Төрле уен коралларын: бик оста һәм дәртләнеп уйнау. *Бию көен сыздыру.* □ *Заһит баянын сыздырып җибәрде.* М. Шабаев. *Кайдадыр курайчы сыздыра курайны.* М. Сөндекле. *Берәү саз сыздыра анда, Итеп тәэсир бөтен җанга.* М. Гафури. || Бик матур һәм оста җырлау. [*Радиодан*] *Гөлсем Сөләймановның „Әллүки"ләрне сыздырулары яңгырап тора.* М. Әмир. || Бик матур сайрау. *И сайрыйлар да инде*

былбыллар! Берсеннән-берсе --- дәртлерәк сыздыралар. Г. Әпсәләмов. || *сөйл.* Бик оста бию.

4. *күч. сөйл.* Китү, юнәлү (гадәттә качып). *Бер диңгез корабына кача-поса кереп утыралар да әйдә — сыздыралар болар әлеге шул Африка дигән якларга.* Н. Дәүли.

СЫЗЛАВЫК *и.* Бик сызлый торган, үлекле вак шеш. *Ул тойгы миңа тынгылык бирмичә, тишелмәгән сызлавык кебек үзен гел сиздереп, гел мазалап тора.* С. Сабиров.

СЫЗЛАНУ *ф.* **1.** Тән сызлап яки организмның берәр әгъзасы авыртып, газаплану. *Зиннәтнең госпиталь-дәге тормышы баштарак сызлану белән үтте.* Г. Бәширов. *Ул, чамасыз сызлануына карамастан, ыңгырашу тавышы чыгармады.* А. Шамов.

2. Рухи газаплану: кайгыру һ. б. ш. *Сызланып, Кадермәт хатыны Зөмәрәне искә төшереп алды. Сагынудан түгел, болай гына.* Ш. Бикчурин. *Әйдә, көнләшеп сызлансын, Газаплансын моңлы ай.* Ә. Ерикәй. || Берәр нәрсә яки кеше өчен нык борчылу, кайгыртучанлык күрсәтү. *Ул, милләтнең нинди генә күңелсез яклары булса, һәммәсе өчен уф орды, әрнеде, көйде, сызланды.* Ш. Әхмәдиев. *Федоров дәшмичә, үз алдына уйланып, башын чайкап утыруында булды. --- Кыйммәтле орлыклар табып та, аларны халыкка бүләк итә алмавына сызлана иде.* А. Расих.

СЫЗЛАНУЛЫ *с.* Сызлануны белдерә, сызланганда була, чыга, әйтелә торган (тавыш, ыңгырашу, аһ-зар турында). *Сызланулы караш. Сызланулы хәрәкәт.* || Сызланып үтә торган (вакыт турында).

СЫЗЛАТУ *ф.* Сызлау яки сызлану китереп чыгару, шуңа сәбәпче булу. *Артык баллы нәрсәнең тешне сызлатуы. Колакны сызлата торган ачы тавыш. Агулы иснең башны сызлатуы. Сагышның җанны сызлатуы. Уңышсызлыкның күңелне сызлатуы. Мәхәббәтнең йөрәкне сызлатуы.*

СЫЗЛАУ *ф.* Әрнетеп, авыртып тору (тән, әгъзалар, организмның берәр жире турында). *Теш, маңгай, баш, колак, беләк, бармак, аяк, бил сызлау. Яра, шеш сызлау.* □ *Карчык уфылдап, сөякләре сызлауга зарланып урыныннан көчкә күтәрелде.* И. Гази.

СЫЗЛАУЛЫ *с.* Сызлый торган (тән, әгъзалар, организмның берәр жире турында). *Сызлаулы билне салкыннан саклау. Сызлаулы яра.* □ *Фазылҗан абзый, сызлаулы аякларын ничек тә суза алмыйча, сүзсез генә пошыргаланып утыра.* Р. Төхфәтуллин.

СЫЗЛАУСЫЗ *с.* Сызламый торган; сау-таза.— *Аяк-кулларыгыз сызлаусыз булсын, җиңгиләр!* М. Фәйзи.

СЫЗМА I *с.* **1.** Сызып эшләгән, сызым рәвешендәге. *Яңа корал нинди булачак, аны Гросман үзе дә белми. Ул тик сызма план буенча жир астына куыш казытырга тиеш иде.* Н. Дәүли.

2. *и. мәгъ.* График схема, сызым. *Моннан биш кенә ел элек бу урында шаулап иген үсеп утырганлыгына, шәһәрнең ул вакытта архитектор --- проектларында һәм сызмаларында гына булуына хәзер ышанасы да килми.* Каз. утл. *Төзү эшләре остасы Габдулланың --- үзе эшләгән план-сызмаларын шәһәр идарәсенең архитектура бүлегендә раслатып, төзәтмәләр кертеп йөргәнен хәтерлим.* И. Рәмиев.

3. *и. мәгъ.* Башлангыч рәвешендә, бик гомуми генә эшләп куелган язма хезмәт, әсәр һ. б.; каралама. *Мин моның турында бүген уйланырмын. Ипташлар белән сөйләшеп, бәлки план сызмасын да ясап булыр әле.* А. Расих. *Мондый юл сызмалары, аерым тотып алырлык әһәмиятләре булса, газета битләрендә аерым факт-очерклар рәвешендә басыла алалар.* М. Җәлил.

СЫЗМА II *с. махс.* Киң ара белән чәчеп, утыртып, рәт араларын эшкәртеп игелә торган. *Сызма культу, ралар.* || Шундый культуралар белән эш итә торган (игенчелек, анын тармаклары һ. б. турында). *Сызма чәчү әйләнеше.* □ *Игенчелектә интенсив сызма системага күчү гаять зур файда китереп кенә калмады, яңа перспективалар ачты.* Соц. Тат.

СЫЗМАЛЫ *с. к.* сызма II. *Җир кипшенгән, һәм бөтен көчне сызмалы культураларны утау эшенә ташларга кирәк иде.* А. Шамов.

СЫЗУ I. *ф.* **1.** Сызыкны: үткәрү, оулдыру, ясау. *Туры яки дулкынлы сызык сызу.* || Сызык кую, үткәрү, сызык билгесе төшерү. *Линейка яки циркуль белән сызу. Сүзләрнең астына сызу. Матур итеп сызарга өйрәнү.* || Очлы нәрсә белән: сызык рәвешле эз ясау. *Җиргә таяк белән сызу. Алмаз белән сызу.* □ [*Янгураз*] *кылычы белән җирне сыза.* Н. Исәнбәт. || Сызык рәвешле эз калдырып үтү (төрле нәрсә турында). *Таш китә асманда [күктә] атылып, ут сызып, Нечкә нурдан ак сымак койрык сызып.* Ш. Бабич.

2. Сызым п. б. ш. [нәрсәне: эшләү, үтәү, ясау. *Схема сызу. Конструкторның машина сызымын сызуы.* □ *Чыбык белән җиргә шакмаклар сызып маташа* [*малай*]. А. Әхмәт. [*Фирдәүс*] *яңа график сызды, бик пөхтәләп сыер савучыларның исемлеген язды.* М. Хәсәнов.

3. Ашык-пошык һәм әз генә язу. *Моны тәрҗемә итеп бирегез! дип бер генә сүз белән сызды да, докладын дәвам иткән килеш, кәгазьне президиумга сузды* [*докладчы*]. Г. Ибраһимов.

4. Язган, рәсем итеп төшергән һ. б. ш. нәрсәнең өстеннән сызыклар үткәреп яки бүтәнчә каралтып, бозу, буяп-пычратып яраксызга чыгару, бетерү. *Ул хатны укып чыкты, байтак сүз һәм җөмләләре аңа ошап җитмәде. --- Шулай да ул аларны сызмады. Хатны конвертлап, адресын язды.* Ш. Камал. [*Шүк бала*] *карандаш белән бу кенәгәнең бер-ике битен сызгалап бозып бетергән иде. Гөнаһ шомлыгына каршы, бу сызган җир бирәчәкләрне язган биткә туры килмәсенме!* Ш. Мөхәммәдев. || Язуның, хәрефнең, сызымның өстеннән сызык үткәреп, аларны дөрес түгел дип билгеләү. *Дниләре фәләненче бит, фәләненче юл, фәләненче хәрефне сызып яңаны язып куйган икән, болар да* [*укытучы булып уйнаучы балалар*] *шулай сызып яңаны яздылар.* Г. Гобәй. || Төшереп калдыру (исемлектән һ. б. ш.). *Сайлау бюллетененнән кайбер кандидатларны сызу. Чираты үткәннәрне исемлектән сыза бару.* || *күч.* Элек әйтелгәнне-язылганны: юкка чыгару, инкяр итү, яраксыз дип табу.— *Кичә басканны бүген сызып утырырга* [*капма-каршы раслау белән чыгарга*] *газета ул, әнем, балалар уены түгел.* Г. Бәширов.

5. Кабызу өчен берәр нәрсәгә ышкып җибәрү (шырпыны). *Шырпыны сызгычына сызып кабызу.* || Кабызу (шырпыны). *Галәү бабай шырпы сызды да корымланып беткән унлы лампаны кабызды.* Г. Гобәй. || Скрипкә сызгычын: ышку, ышкып йөртү. *Сызгычны канифольләп сызу.*

6. *күч.* Чыбыркы, чыбык һ. б. ш. нәрсә белән: сугу. *Ул камчы белән янбашка яман китереп бер сызды. Айгыр дулап-дулап далага чапты, егет аның белән бергә очты.* Г. Ибраһимов. [*Хәлфә*] *бер кат күлмәкчән аркага бер-ике рәт сызып җибәргәч, күз алдымда йолдызлар күренде.* Х. Садрый.

7. Үткәрү, салу, ясау, яру (буразнаны һ. б. ш.). *Ызан сызу.* □ — *Газинур, беренче буразнаны туры сыз.* Г. Әпсәләмов. || *махс.* Буразна, рәт арасын йомшарту, чүп үләннәрдән арындыру.— *Зәйнетдин,*

тордыңмы? Бүген бәрәңге сызарга чыгабыз. Ат башыннан тотып йөрерсең. Б. Камалов.

8. *күч.* Билгеләү, күрсәтү, алдан ачыклап кую (үсеш, киләчәккә бару юлларын, тормышның юнәлешен һ. б. ш.). *Партиянең сызган юлларын үткәрергә кирәк иде.* Г. Ибраһимов. *Ленин сызган якты юлдан Тайпылмыйча бардык без.* Ә. Ерикәй. || Төзү, эшләү, кору (планнарны). *Без бергәләп трактор заводы каршы алу, бу вакыйгага халыкны әзерләү планнарын сыздык.* М. Әмир.

9. *күч.* Бик оста, матур уйнау (уен коралларын). *Гармун сызу.* □ *Әпсәләм белән [Миңдүш] карак-каршы биләр ди, скрипкәне сызалар ди.* Г. Газиз. *Шул вакытта сазын сызды көйгә салып, Сузып-сузып, саф тавышлы бер кыз торып.* М. Гафури. || Бик матур һәм бирелеп җырлау. *Иштеттем мин матур көйләреңне, Урман ярып сызган җырларың.* Ш. Маннур. || Бик матур сайрау. *Озакламас, матур кошлар килер, Шатлык көен безгә сызарлар.* Ш. Маннур. *Чут-чут итеп сызып җибәрә [былбыл].* М. Гафури.

10. *күч. сөйл.* Качып, куркып һ. б. ш. рәвештә берәр җирдән китү (гадәттә тиз генә). *[Байларның] күбесе беренче шартлауны ишетү белән үк --- әйберләрен төяп Казаннан кырык-илле чакрым ераклыктагы авылларга, дачаларга сызды.* К. Нәҗми. *Бары да сызды, бары да тайды, Бушка әйләнгәч шул кесә.* З. Бәшири. || *боерык форм.* Куып җибәргәндә әйтелә.— *Сызыгыз күз алдымнан яхшы чакта!* Ф. Бурнаш.— *Әйдә, эшеңне тизрәк бетер дә чыгып сыз әле моннан.* Х. Җәмил.

СЫЗУ II *ф.* **1.** Төрле нәрсә тәэсирендә әкрен-әкрен генә ашалып-кимеп, кечерәеп-юкарып калу яки бөтенләй юкка чыгу. *Менә шул сызып кына яткан күмерләрне дөрләтеп кабызыр өчен кирәк булган шифалы, саф җилләр исә башлады инде.* М. Хәсәнов. *Кулыңдагы көмеш йөзек Сызып бетсә нишләрсең?* Җыр. *Яңгырдан соң кояшка аркасы белән торган җирләрдәге карлар да бик тиз сызып бетә.* Ә. Еники. || Эрү (түшкә, эч мае турында).

2. *күч.* Ябыгу, чандырлану, зәгыйфьләнү (әгъза, гәүдә, кеше турында). *Аның бөтен гәүдәсе ут булып яна, мәһабәт тән шул уттә күзгә күренеп сыза иде.* Г. Бәширов. *Әби белән бабай күзгә күренеп сыздылар. Әби инде пинкәгә [сүс тетәргә] дә ярамас булды.* Г. Гобәй.

3. *күч.* Кайгыру, кайгыга-хәсрәткә бирелү. *Тик күңелгә нидер җитми кебек, Эчтән генә сызып моңаям.* Ф. Кәрим. *Әлеге кешенең тормышы шундый бит: әгәр ялгыз башың гына сызып йөрсәң, кайгы сине басып сытачак.* К. Нәҗми.

СЫЗЫК I *и.* **1.** Нечкә генә буй билге, озынча эз. *Дәфтәр сызыгы. Горизонталь сызык. Дулкынлы сызык.* □ *Ауган агачлар буйлап сыртларына сары сызыклар төшкән борындыклар чабыша.* Ә. Маликов. || Берәр нәрсәнең нечкә генә булып сузылган эзе, юлы. *„Катюша“ миналары яман сызгырып, артларыннан утлы сызыклар калдырып, бер-бер артлы дошман оборонасы ягына очты.* Каз. утл. || *мат.* Ике ноктаны тоташтыра торган билге, эз. *Туры сызык. Кәкре сызык.*

2. Бүлеп, аерып тора торган (чын яки шартлы) билге, чик. *Су күтәрелеше сызыгы. Фронт сызыгы. Экватор сызыгы. Горизонт сызыгы.* □ *Менә бу чирәмлек Энәле кыры белән бәзнең авыл кырын аера торган сызык була инде.* З. Бәшири. *Чик сызыгы булып елга ага.* Ф. Кәрим.

3. *грам.* Озын горизонталь туры формасындагы тыныш билгесе. *Автор сүзләре белән туры сөйләм арасына язуда сызык куя.* □ *Ия белән хәбәр арасында кайчан сызык куярга кирәклеге турында журналистлар арасында әледән-әле бәхәс куба иде.* Соц. Тат.

4. Тәндә: җыерылу яки җыерчыкланудан барлыкка килгән һ. б. ш. озынча эз, юл, сыр. *Ул күзгә күренеп ябыкты; --- яңак сөякләре калыкты, ике каш арасындагы сызыгы тирәнәйде.* И. Гази. *Аның йөзендәге ачуны гажәпләнү сызыклары алмаштырды.* Г. Минский. *Аның йөзенә сарылык иңгән, күз төпләрен шәмәхә сызыклар баскан.* Каз. утл.

5. Берәр сыйфат, үзлек, билге. *[Тукай] табигатендәге гайре табигый бу сызык [хатын-кыздан качу] кайдан килгән вә нидән хасил булган?* Ф. Әмирхан. *Бу сатирик пародияләр Каригвның чиктән тыш нечкә күзәтүчәнлеген, типның характерлы сызыкларын эләктереп алу осталыгын --- күрсәтә.* И. Рәмиев.

6. Сәнгатьтә, бигрәк тә әдәбияттә: бер юнәлеш, үзенчәлекле як. *Революциягә кадәрге татар әдәбиятының үсеш юлында бу ике омтылыш һәм бу ике сызык — реакцион һәм демократик сызыклар — бик ачык күзгә ташланалар.* М. Җәлил. *Бигрәк тә тел мәсьәләсе балалар әдәбияты сызыгы буенча нык кына бәхәс кылынырга тиешле.* Ф. Кәрим.

СЫЗЫК II *и.* Туң май эреткәндә төер-төер куырылып кала торган азык. *Ашар идек кызып, җитмәгән сызык сызып.* И. Туктар.

СЫЗЫКЛЫ I *с.* **1.** Өстенә сызык I (1 мәгъ.) сызылган (кәгазь һ. б. турында). *Сызыклы дәфтәр.* □ *[Тикшерүче] өстәл астыннан сызыклы бланк чыгарды.* Ш. Маннур.

2. Җир, кәгазь кебек нәрсәгә сызыклар сызып уйнала торган (бала-чага уеннары турында). *[Дүрткүз] сызыклы уйнаучы кызлар белән шаярырга тотына.* Р. Батуллин.

СЫЗЫКЛЫ II *с.* **1.** Сызык II салып әзерләнгән (аш һ. б. турында). *Сызыклы бәрәңге ашау.*

2. Эреткәндә сызыгы (күп) чыга торган (май турында).

СЫЗЫКЧА *и.* Кыска гына, кечкенә генә сызык I (1, 4 мәгъ.). *[Мәдинәнең] йөзендә җыерчыклар бөтенләй күренми диярлек. Тик күз тирәләрендә генә бераз пәрәвез челтәренә охшаган сызыкчалар бар кебек.* М. Хәсәнов.

2. *грам.* Ярты сызык I (3 мәгъ.) озынлыгы тыныш билгесе; дефис. *Парлы яки кабатлаулы сүзләрне сызыкча белән язу. Сүзне бер юлдан икенче юлга күчергәндә сызыкча кую.*

СЫЗЫКЧА *с. мат.* **1.** Озынлыкка һәм шуңа бәйле зурлыкларны үлчәүгә мөнәсәбәтле; *русчасы:* линейный. *Сызыкча берәмлек. Сызыкча үлчәнеш. Сызыкча тизгезләмә.*

2. Туры сызыкка мөнәсәбәтле; *русчасы:* линейчатый. *Сызыкча геометрия.*

СЫЗЫЛУ I *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сызу I (1, 2, 4, 5, 7, 8 мәгъ.).

2. Сызык рәвешле сузылып китү. *Сызылып мыек чыгу. Кара кашның сызылып торуы.* □ *Ул яшь әле. Ләкин аз гына кысык күзләре тирәсенә инде җыерчыклар сызыла башлаган.* Н. Дәүли. *Тау башыннан сызылып сукмак үтә.* Ә. Ерикәй. *Тәрәзәдән сызылып кергән беренче нурлар авыру Фәйзинең битен һәм күңелен кытыкладылар.* Ф. Әсгать.

3. Беленә, күренә башлау (таң, шәфәкъ турында). *Шәфәкъ сызылу.* □ *Таң сызылганчы без Миус суын кичтек.* И. Гази.

СЫЗЫЛУ II *ф.* Борчылу, әрнү (күнел, йөрәк турында). *Күкрәккәем сызыла, тәнем яна.* М. Җәлил.

СЫЗЫМ *и.* **1.** Яссылыкта (мәсәлән, кәгазьдә, тактада һ. б. ш.) сызыклар белән бирелгән сурәт, график схема; сызып эшләнгән хезмәт. *Геометрик сызымнар.*

Яңа марка станокның сызымнары. Детальне нәкъ сызымда бирелгәнчә төгәл эшкәртү. □ *Илфарның баш архитектор белән бергә сызымнар өйрәнгәне, киңәшкәне бар.* Б. Камалов.

2. Сызым сызу эшләре турындагы фән тармагы; *русчасы:* черчение. *Сызым дәресе.*

СЫЗЫМТА *и.* Берәр нәрсәнең чак кына беленеп торган тышкы рәвеше. *Менә басу капкасыннан хуторга керәм дигәндә генә кинәт томан эченнән ике җайдаклының тоныкъ сызымталары калкып чыкты.* Каз. утл.

СЫЗЫМЧЫ *и.* Сызымнар сызучы, шул эштә эшләүче. *Бу егет --- институтның ниндидер бер бүлегендә сызымчы булып эшли иде.* Азат хатын.

СЫЙ *и.* **1.** Бәйрәмдә ашала, кунакка тәкъдим ителә торган, яхшырак-затлырак ашамлык-эчемлек һ. б. ш. *Бәйрәм сые. Кунак сые.* □ *— Кара аны, Хәлил, туйда сыйны мул яса.* М. Фәйзи. *Яшел суганнан алып редискасы, кыяры, помидоры авылда иң алдан өлгерә торган бакчалары бар иде аларның. Безне, кергән саен, әнә шул бакча сыйлары белән каршылый алар.* Р. Төхфәтуллин.

2. Сыйлау-сыйлану өчен оештырылган мәҗлес. *Сыйга чакыру. Сый оештыру.* □ *Самовар шаулап кайнап чыкты. [Болынга] алып килгән чынаякларга --- чәй ясалды. Сый башланды.* Ә. Фәйзи.

3. *күч. ирон.* Җәза, җәбер һ. б. ш. [*Бүрегә атучы:*] *Мә алайса, көткән сыйны Ал син бездән, ал; Күп ерткычлыклар эшләдең, Бәдбәхет, кадал!* А. Алиш. *— Ирек даулаганда Деникин бандаларының сыен татыдым.* Э. Касыймов.

◇ **Сыйда йөзү** — сыйлы тормышта яшәү. *Сыйда йөзә поплар, муллалар.* Ә. Ерикәй.

СЫЙДЫРУ *ф.* **1.** Берәр нәрсә сыяр өчен җитәрлек зур, киң, иркен булу. *Мичкәнең илле чиләк су сыйдыруы.* □ *Унлап амбар сыйдыра алмый Бу ел уңган игенне.* М. Җәлил.

2. Сыярлык, урнаштырырлык урын табып, берәр нәрсәне шунда урнаштыру яки берәр җирдән үткәреп җибәрү. *Китапларны бер букчага сыйдырып бетерү.* □ *Карчык кулындагы ботаклы агачны тимер мичнең кечкенә авызына сыйдыра алмый сукранып алды.* Ә. Фәйзи. *Алтын рамлы зур түгәрәк көзге. Гомердә онытасым юк, ишектән сыйдыра алмыйча теңкәбез корды.* Ф. Хөсни.

3. Берәүгә сыену урыны бирү, үз янына алу.— *Эти үзе барында да сыйдырмаган яшь әни янына, әлбәттә, кайтмадым инде.* М. Фәйзи.

4. Мөмкинлек бирү, булу (вакыт турында).— *Вакыт сыйдырмый бит, Зөлфия, вакыт!* Р. Ишморат. *Вакытыгыз сыйдырса, кичке салкында мине бакчаларыгызда йөртерсез.* Ш. Әхмәдиев.

5. *күч.* Яраштыру, туры китерү (законга, статьяга, нормага һ. б. ш.). *Шәригатькә сыйдыру.* □ *Ул моны кичектер* [*законга*] *сыйдырды.* А. Шамов.

СЫЙДЫРЫШ *и.* Сыйдыру мөмкинлеге, күрсәткече. *Суднонының сыйдырышы зур булу.*

СЫЙДЫРЫШЛЫ *с.* Сыйдыра торган, сыйдыра алырлык. *Алты мең кеше сыйдырышлы тамаша залы бик зур булырга тиеш иде шикелле. Ләкин ул җыйнак итеп эшләнгән.* Г. Әпсәләмов.

СЫЙДЫРЫШЛЫЛЫК, СЫЙДЫРЫШЛЫЛЫК *и.* Сыйдыру, сыйдыра алу мөмкинлеге, дәрәҗәсе. [*Кетәкнең*] *сыйдырышлыгы — өч мең баш иде.* Соц. Тат.

СЫЙЛАНУ *ф.* Сый итеп биргәнне ашау, эчү һ. б.; бик ләззәт белән ашау, эчү һ. б. *Алма белән сыйлансыннар — эштә уңганнар гына.* М. Җәлил. *Синдә тәмәке бар бугай, сыйланып алыйк булмаса!* Ә. Фәйзи.

СЫЙЛАУ *ф.* **1.** Киң күңелллелек, кунакчыллык күрсәтеп, ашарга, эчәргә бирү яки тәкъдим итү; кунак итү. *Дус итеп сыйлау. Кунак сыйлау. Өмәчеләрне сыйлау.* □ *Сыйлап биргәннең суын эч.* Мәкаль. *Әби ак тавыгын бик ярата, аны төрле җим белән сыйлый.* А. Алиш.

2. *күч. ирон.* Җәзалау, кыйнау. [*Бай — үзенә карышучыларга:*] *Әмма яхшы белегез: дәтмәсәгез, оланнар, Йомшак җирегезне Камчы белән сыйлар!* Ш. Маннур. [*Дошманны*] *башлап, мин сиңа әйтим, дус кеше, типкәләп урыннарыннан кузгаталар. Аннары шрапнель белән бераз сыйлап алалар.* А. Шамов.

СЫЙЛЫ *с.* **1.** Сыйлар куелган, сыйлау өчен әзерләнгән (табын һ. б. турында). *Эри таш күңел сыйлы табында.* Ә. Юныс. *Амбарлар тулы, табыннар сыйлы.* Азат хатын.

2. Сые була торган, сыйларга яратучы. || Сые (күп) булган, сыйланып яшәүче. [*Көтүче:*] *Башка кешеләргә карағанда җәенда сездә тамак сыйлырак булыр дип уйлыйм, Насыйр абзый.* М. Гали.

3. Сый белән, яхшы ашау-эчү белән үтә торган (тормыш турында). *Сыйлы көнең — сыер белән.* Мәкаль.

СЫЙНФЫЙ *с.* Сыйныфка (I) мөнәсәбәтле. *Сыйнфый көрәш. Сыйнфый каршылыклар. Сыйнфый бердәмлек. Сыйнфый дошман. Сыйнфый аерымлыклар.* || Берәр сыйныфка, аның идеологиясенә хас. *Сыйнфый караш. Сыйнфый аң.*

СЫЙНЫФ I *и.* „Сыйныфлар дип иҗтимагый җитештерүнең тарихи яктан билгеле бер системасында тоткан урыннары буенча, җитештерү средстволарына (күбесенчә закон белән беркетелгән һәм формалаштырылган) мөнәсәбәтләре буенча, хезмәтне иҗтимагый оештырудагы рольләре буенча һәм, димәк, иҗтимагый байлыкны алу ысулы һәм алар өлешенә тигән иҗтимагый байлыкның күләме буенча аерыла торган кешеләрнең зур группалары атала". В. И. Ленин. *Эшче сыйныф. Капиталистлар сыйныфы. Антагонистик сыйныфлар.* □ *Тарих — сыйныфлар көрәшенең көзгесе.* Г. Коләхметов. *Изелгән сыйныфларның кул-аягындагы богаулар чишелде.* М. Гафури.

СЫЙНЫФ II *и. к.* класс (2 мәгъ.) *Ул дүрт сыйныф авыл мәктәбен үткән кыштан элекке кышны бетергән иде.* Ш. Камал.— *Инде сыйныфны яңадан җыеп алып булачак түгел. Гомәр хәлфәнең күпме көч куеп җыйган сыйныфын тараттым бит. Ни дип җавап бирермен аның алдында?* Ә. Фәйзи. *Беренче мәртәбә укытучы булып сыйныфка кергәндә аяк-кулларым калтырады.* Ж. Фәйзи.

СЫЙНЫФЛЫ *с.* Сыйныфларга (I) аерылган, сыйныфлардан торган (җәмгыять турында). *Безнең иң яхшы дигән әсәрләребездә дә сыйнфый тенденциялелек үзен шактый ачык сиздерә килде. Без моны кимчелек итеп тә санамадык. Һәм хәзер дә сыйныфлы җәмгыять логикасына буйсынган ул чорлар әдәбиятына карата кимчелек итеп санамыйбыз.* М. Әмир.

СЫЙНЫФСЫЗ *с.* Иҗтимагый сыйныфлардан тормаган, сыйныфларга аерылмаган (җәмгыять турында). *Сыйныфсыз җәмгыять төзү ул бер сыйныф та калдырмау дигән сүз инде. Шуның өчен ул сыйныфсыз җәмгыять дип атала да.* М. Җәлил. *Авырлыклар каршы бәрелсә дә, Арка белән җиргә ятмыйбыз. Көрәш белән, Без сыйныфсыз илгә Батырларча аяк атлыйбыз!* М. Крыймов.

СЫЙНЫФТАШ I *с.* Бер үк сыйныфтан (I) булган. *Пролетариатның чыгышлары фашизмга, сугышка һәм монополияләргә каршы, сыйныфташ туганнарны интернациональ яклау лозунглары астында бара.* Соц. Тат.

СЫЙНЫФТАШ II *с. иск. к.* классташ. *Мәдрәсәнең югары сыйныф шәкертләре, башка һәркайдагы кебек, монда хәлфә-хәзрәт, байлар яклы булалар. Ләкин Нигъмәт казый аерым юл алды, сыйныфташларыннан аерылып, шәкерт хәрәкәте эченә кушылды.* Г. Ибраһимов. *Алар рабфакта сыйныфташ иптәшләр.* Ш. Камал.

СЫЙНЫФЧЫЛЫК *и.* Сыйнфый нигездән чыгып карау, эш итү практикасы, тәртибе. *Пролетариат әдәбиятында төп нигез булган, аны башка әдәбиятлардан аерган моментларның башлычалары: динамика, көрәш, сыйныфчылык, коллективизм, хезмәт һәм интернационализм.* Г. Ибраһимов.

СЫЙПАЛАНУ *ф.* **1.** *к.* сыйпану. [*Мәдинә*], *әнкәсенә күрсәтмәскә тырышып, киеменә тиз-тиз генә исле май сеңдерде, көзге алдында туктап сыйпалангандай итте дә, кулына бәйли башлаган оегын-инәсен алып, чыгарга җыенды.* Н. Фәттах.

2. Назланып сыену, иркәләнү; сырпалану. *Мәченең аяк астында сыйпаланып йөрүе.*

СЫЙПАЛАУ *ф. Каб. дәр. к.* сыйпау. || Сыйпау. *Этне-мәчене сыртларыннан сыйпалау.* □ *Аны шунда ук кызганырга, юатырга тотыналар, мескенкәй, ятимкәй диләр, сөяләр, сыйпалыйлар.* Ш. Еникеев.

СЫЙПАНУ *ф.* Киеменне, чәченне рәтләп-сыйпап, үзеңне бик пөхтәләп тору; төзәтенү.

СЫЙПАУ *ф.* **1.** Җиңелчә, йомшак кына сыпыру. *Мыек сыйпау.* □ [*Галимә*] *кара чәчләрен сыйпап артка төшерде.* М. Гафури. *Безнең кардәш Сафа карт та ак сакалын сыйпап бу сүзне куәтләп куя.* Г. Ибраһимов. || Шул рәвешчә сөю, иркәләү. *Баштан сыйпау. Аркадан сыйпау.* □ *Ат яныннан чыгып китәр алдыннан* [*Газинур*] *тагын берничә тапкыр аның муенынан сыйпап алды.* Г. Әпсәләмов. *Солтан, чүгәләгән килеш, этенең аркасын сыйпый.* Г. Бәширов.

2. Җиңелчә, йомшак кына тиеп-кагылып үтү (җил һ. б. турында). *Маңгай чәчен сыйпый җилләр.* Ә. Юныс. *Уләннәрне сыйпап җил исә.* Ф. Кәрим.

СЫЙРАК *и.* Аякның тездән тубыкка кадәр өлеше. *Нечкә сыйрак. Ат сыйрагы.* □ *Әнкәсе улының озын сыйракларына, киңәя башлаган җилкәләренә карап, сокланып куя.* И. Гази. *Анда эт сыйрагы ычкынмаслык пычрак була.* К. Нәҗми.

СЫЙФАТ I *и.* **1.** Берәр нәрсәгә яки кешегә хас үзлек, билге; нинди булса да бер үзенчәлекне чагылдырган аерымлык. *Уңай яки кире сыйфатлар. Шәхси сыйфатлар.* □ *Тыйнаклык — күркәм сыйфат.* Г. Гобәй.— *Син бөтен матур сыйфатларны үзеңә җыйгансың.* М. Фәйзи. *Кеше күпме генә үзгәрмәсен — әүвәлге сыйфатларын бервакытта да җуеп бетерми.* Ә. Еники.

2. Берәр нәрсәнең яхшылык, кыйммәтлелек, яраклылык дәрәҗәсе. *Эшнең сыйфатын яхшырту. Чәчүнең сыйфатын тикшерү.* □ *Сыйфатны да яхшы итегез, Күтәрерлек булсын ил данын!* Ә. Исхак. *Балалар китапларының темаларындагы бертөрлелек --- аларның сыйфатын төшерә.* М. Җәлил. || Яхшы сыйфатлылык. *Илдә сыйфат өчен көрәш бара.* Һ. Такташ.

3. Кыяфәт, килеш-килбәт. *Ул үзе тәбәнәк кенә, башында озын йонлы зур бүрек булып, тавыш вә сыйфатыннан карт кеше икәнлеге аңлана иде.* Ш. Камал. *Мин патша, миндә кешенең ни эше бар,— дигән бер кыяфәт белән, киберле генә бер сыйфатта утырды да кыйблага карап юнәлде* [*Җәләл*]. Г. Ибраһимов.

4. *филос.* Әйбернең әһәмиятле үзенчәлекләрен, билгеләрен эченә алган төп асылы. *Сан-микъдарның сыйфатка күчүе. Сыйфат үзгәрешләре.*

5. *бәйл. функ. кит.* **сыйфатында, сыйфаты белән.** „Шундый кеше буларак“ дигәнне белдерә. *Читтән килгән бер күзәтче сыйфатында йөрүче бер кеше генә ул.* М. Гали. *Тукай, халык шагыйре булмак сыйфаты белән, яшь әдәбиятыбызга, яшь матбугатыбызга зур хезмәт керткән кеше.* Ф. Әмирхан.

СЫЙФАТ II *и. лингв.* **1.** Предметның берәр билгесен белдерә торган сүз төркеме. *Асыл сыйфат. Нисби сыйфат. Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатның җөмләдә аергыч булып килүе.*

2. *с. мәгъ.* Шушы сүз төркеме функциясен үти торган. *Сыйфат сүз.*

СЫЙФАТЛАМА *и.* Берәр нәрсәне сыйфатлау бәяләмәсе; тасвирлама. *Әдәби образга сыйфатлама бирү.*

СЫЙФАТЛАНМЫШ *и. лингв.* Сүз тезмәсендә яки җөмләдә сыйфат (II) тарафыннан ачыкланып, сыйфатланып килгән сүз. [*Каюм Насыйри*] *русча яки халыкара сыйфат һәм сыйфатланмыштан гыйбарәт булган катлаулы терминнарны биргәндә сыйфатларны күбесенчә ир җенес (муж. род) формасында гына куллана.* Ш. Рамазанов.

СЫЙФАТЛАУ *ф.* Тасвирлау. *Табигать күренешләрен бирүдән тыш, әдип тагын иҗтимагый күренешләрне сыйфатлауда да --- зур осталык күрсәткән.* Г. Нигъмәти. [*Тикшерүче*] *җинаятьнең урынын сыйфатлап язды.* Г. Ибраһимов. || Бәяләү, бәяләмә бирү. *Чегәннәрне ат белән сәүдә итүчеләр дип кенә сыйфатлау — милли антагонизмга нигезләнгән әшәке бер чыгыш.* М. Җәлил.

СЫЙФАТЛАШУ *ф. лингв.* Сыйфатка (II) әйләнү, бүтән сүз төркеменнән сыйфатка күчү. *Сыйфатлашу процессы нәтиҗәсендә башка төркемнәрдән булган сүзләрнең бер юлы сыйфатка күчеп, бөтенләй сыйфат булып киткәннәре дә бар.* В. Хангилдин.

СЫЙФАТЛЫ *с.* Яхшы сыйфатлы. *Иң беренче, иң сыйфатлы ашлык Бүләк булсын туган илемә!* С. Урайский. *Казан кирпеч заводында бер шаян кыз Мәрфуга Сәгатенә сигезәр мең сыйфатлы кирпеч суга.* М. Сөндекле.

СЫЙФАТЛЫЛЫК *и.* Сыйфатлы булу үзлеге, хәле һәм дәрәҗәсе. *Орлыкның сыйфатлылыгын билгеләү. Эшнең сыйфатлылыгы өчен тырышу. Продукциянең сыйфатлылыгын күтәрү.*

СЫЙ-ХӨРМӘТ *и.* **1.** Хөрмәт белән тәкъдим ителә торган сый, сыйлар; хөрмәтләп сыйлау-сыйлану. *Сый-хөрмәт күрсәтү. Сый-хөрмәт мәҗлесе.* □ *— Кунакка кайт, абый, кунакка кайт, Сый-хөрмәттән бер дә тарсынмам.* Ш. Маннур. *Ачык чырай булганда, аннан да тәмле сый-хөрмәт юк инде.* А. Шамов. || Сыйлау-сыйлану мәҗлесе. *Бүген, сый-хөрмәттән кайтуына карамастан, аның кәефсезлеге кечкенә түгел иде.* Ш. Камал.

2. *кыек килеш форм.* Сыйлы, сый-хөрмәтле тормыш. *Сый-хөрмәттә гомер итеп картаючылар. Ата-анасын сый-хөрмәттә генә яшәтүчеләр.*

СЫККЫЧ *и.* Үсемлек майларын сыгып алу (чыгару) һ. б. ш. җайланмасы, аппараты, кораллы.

СЫКРАНУ *ф.* **1.** Җиңелчә ыңгырашу. [*Самолетта*] *күп кенә яралы солдатлар да бар, кайберләренең башлары, кайберләренең куллары бәйләнгән, берничәсе носилкаларда сыкранып ята.* Г. Гобәй. || Ераклашмас кына әһелдән кәефсезләнү һ. б. (бала-чага турында). *Абзалары кай чагында Сәгыйдәнең назлану вә сыкрануларына әчләре пошса да, әмма күңелдән аны сөя иделәр.* Ш. Камал.

2. Кайгырып зарлану, ухыру, уфылдау. *Ул язмышы каршында тезләнми, өметсезләнү һәм сыкрануның нәрсә икәнен белми.* М. Максуд. *Безгә хас түгел*

Елау, сыкрану. М. Җәлил. *Сыкранулар, әрнү, моңланулар Табылмаслар безнең җырларда.* Ә. Исхак. || Күңел һ. б. ш. турында: борчылу, сызлану. *Нәсимәнең йөрәге сыкранып китте.* Д. Аппакова. *Аның күңеле һаман-һаман сыкранды:— Тиздәнме инде ипташлар суды булачак?* А. Алиш.

СЫКРАНУЛЫ *с.* 1. Сыкрануны белдергән, сыкрану белән аралаш ишетелә торган (сүз, аһ ору һ. б. турында). *Аның авызыннан бик каты да, бик ачулы да, бик сыкранулы да сүзләр туктаусыз атылып тордылар.* Г. Иделле.

2. Сыкрау-авыртулар белән бергә була торган (тойгылар һ. б. ш. турында). *Аның бөтен тәненнән, татлы газап сыман, нинди дер рәхәт тә, сыкранулы да бер дулкын уза.* Г. Бәширов.

СЫКРАУ *ф.* 1. Җиңелчә ыңгырашу. *Кайберләре, туңган әгъзаларының әрнүенә чыдаша алмыйча, сыкрап еларга керешә.* Т. Гыйззәт. || Елар-еламас кына әһелдәп кәефсезләнү һ. б. ш. (бала-чага турында). *Анасын сагынып сыкрый башласа, без аны:— Елама, әниең тиздән килер,— дип юата торган булдык.* Г. Минский.

2. Җиңелчә сызлау, авырту. [*Мирсәет:*] *Яраң ачылдымы әллә?— Ачылмады ачылуын, аз гына сыкрап тора.* Р. Ишморат. *Ул тагын башын саламга куйды һәм, гәүдәсендәге сыкрауга бирешмәскә теләгәндәй, иреннәрен кысып югарыга, аяз күккә карады.* К. Нәҗми. *Аяк-куллар тала, сыкрый.* З. Бәшири.

3. Кайгырып зарлану, ухыру, уфылдау. *Седов авыруына чыдый алмый үлә. Йөрәкләре белән сыкрый-сыкрый иптәшләре аны күмәләр.* А. Алиш. *Көлүчеләр бүген сыкрый инде.* Ф. Кәрим. *Ул артык йомшак тәнлелек күрсәтә. Мещан кызы артыннан гашыйк булып сыкрап йөри.* Г. Нигъмәти. || Күңел һ. б. ш. турында: борчылу, сызлану. *Күңел сыкрау. Җан сыкрау.* □ *Бүген Гөлнарның яшен күреп тә йөрәгем сыкрады.* Ә. Айдар.

СЫКТАНУ *ф. к.* сыкрану. *Еладым дәхи сыктандым Сагынып бик.* Г. Кандалый. *Алар пароходка утыргач еламый, сыктанмый гына килделәр.* Ш. Камал.

СЫКТАУ *ф. к.* сыкрау (1, 3 мәгъ.). *Йөгереп-йөгереп, туктаган, яулык болгап сыктаган Нәзкәй билем, исән бул!* Дәрдмәнд. *Әрнү, сыкрау, сызланулар соң нигә? Сыктамыйм, әнҗе яшем кыймәт миңа.* Ш. Фидаи.

СЫКТАШ *и.* Сыктау-сыкташу халәте һәм хәле, күренеше. *Урак өстендә сугыш чыкты. --- Көпә-көндез кеше басудан авылга агылды. Елаш та сыкташ китте.* Ш. Маннур.

СЫКЫ *и.* 1. Әйбернең үз парыннан ясалып өстенә утырган юка гына кар катламы (кыраудан башка). *Бәлки чәчкә бераз чал кергәндер, Сыкы төшкән кебек тирәккә.* Ә. Еникәй. [*Тыштан керүченең*] *бүрегенә, иңнәренә сыкы коелган, керфекләрендә дә боз әреп бетмәгән иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Салкын, кышкы һавада сыек томан булып кына җемелдәп күренүче кар бөртекләре. *Январь төне. Тынга кабарлык булып куе сыкы төшкән. Тирә-як тын. Кабер тынлыгы.* М. Хәсәнов.

СЫКЫЛАУ *ф.* 1. Сыкы белән каплану. *Тәрәзә пыяласы сыкылау.* □ *Карчыгын иярткән, сыкылаган сакалын сыпыра-сыпыра тимерче Камали да килеп җитте.* Соц. Тат.

2. Сыкы (2 мәгъ.) белән аралашу (һава турында).

СЫКЫЛЫ *с.* 1. Сыкы белән капланган, сыкылаган. *Кышкы суыкларда кечерәеп калган атлар сыкылы сыртларын сикертеп, урамның нәкъ уртасыннан сузылган шома юлдан станция ягына юырталар.* А. Гыйләҗев.

2. Сыкы (2 мәгъ.) белән аралашкан. *Сыкылы һава.* || Көн турында: һавасында сыкы булган. *Иртә томанлы, сыкылы, салкын иде.* Соц. Тат.

СЫЛАНУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* сылау (1—4 мәгъ.).

2. Ябышып иярү (үзле балчык һ. б. ш. турында). *Пычракның тәгәрмәчкә сылануы.* □ *Ни хәл, егетләр, җир юеш түгелме, калакка сыланмыймы?* М. Гали. *Ашлык коры булса гына бит он йомшак була; кипмәгән ашлык --- ташка гына сылана.* Ш. Камал. *Сутлы балчык итек һәм ботинка олтанарына сылана.* С. Шакир.

3. *сөйл.* Кершән-иннек ише нәрсәләр белән килешсез, әдәпсез бизәнү.— *Нигә соң табигый булган чын матурлыкны ясалма буяулар, сыланулар белән киметәсең, югалтасың?* Ш. Әхмәдиев.

4. Тәннең һәр җиренә тигез тиеп, ятып тору (кием турында). *Балтырга сыланып тора торган куныч. Гәүдәгә сыланып торган свитер.* □ *Аның буй-сынына сыланып торган аксыл зәңгәр күлмәгенең озын, киң итәге аякларына урала.* Каз. утл.

5. *күч.* Берәр нәрсәгә якын ук килеп, аңа елышу, терәлеп үк урнашу. *Ишеккә сыланып тыңлап тору.* □ *Кыз бөтен гәүдәсе белән тәрәзәгә килеп сыланган иде.* Ф. Хөсни. || Шул рәвешле посу, яшеренү. *Разведчиклар җиргә сыланып яталар.* А. Әхмәт. *Малайлар керүләренә ишекнең уң ягындагы стенага килеп сыландылар. Хәлим, үзләре турында белдереп, кыюсыз гына борынын тартып куйды.* Г. Гобәй.

6. *күч. сөйл.* Тыйнаксызлык дәрәҗәсенә җитеп, әрсезләнеп берәүгә елышу, сыену яки иярү, артык куштанлану. *Җанашым бөтен тәне белән миңа сыланды.* Ф. Әмирхан. *Менә бит нинди сагыз бу Миңгаян түти, кунакка тын алырга даирек бирми; сыланса сылана икән кеше, бер алдына биш артына төшә.* С. Рафиков.— *Әй! Күзенә төшкән бер иргә сылана торган хатын икән ләбаса ул!— дигән түбән караш туу бик күңелле түгел ич.* Ш. Камал.

СЫЛАНЧЫК *с.* 1. Сылана, ябышып иярә торган (төрле үзле нәрсә турында). *Мәдинә, яшен тизлегендә, ауган читәнне атлап чыкты да бәрәңгесе казылган бакчаның авыр сыланчык туфрагына батабата, алга карап йөгерде.* Г. Минский.

2. *күч. сөйл.* Әдәпсез саналыр дәрәҗәдә әрсез кыланып, берәүгә елышучы, иярергә тырышучы. *Сыланчык кеше.*

СЫЛАУ I *ф.* 1. Берәр үзле нәрсәне: ябышып калырлык итеп йоктыру, катлам итеп ягу. *Көймә ярыгына сумала сылау.* □ *Багананың яртысыннан уза алмыйча төшкән егет Хәлимнең аяк табанын, уч төпләрен тотып карады:— Аларга ышаныч юк, нарат сагызы сылыйлар алар,— диде ул.* Г. Гобәй. [*Бит очы өшегән малай*] *каз маен бармак башына тидереп битенә сылады.* Л. Ихсанова. || *сөйл.* Ягу (майны, балны һ. б. ш. азыкны).— *Кәримҗан! Шул икраны бик калын итеп булки өстенә сылап бир әле!* Ф. Әмирхан. [*Нуруллин*] *күмәчкә май сылап алды, өстәлдәге графиннан су эчте.* А. Шамов.

2. *күч.* Артык калын һәм килешсез, ямьсез итеп сөртү, йоктыру (буяуны һ. б. нәрсәне). *Тәҗрибәсез яшь кызларның битләренә иннек сылавы. Итеккә күп итеп крем сылау.* || Берәр нәрсә йоктырып пычрату. [*Бер кыз*] *Галәвинең битенә корым буяды. --- Ул торып, мичтән корым алып, кызларның үзләренә сыларга килгәндә Нәгыймә йөгереп барып тиз генә утны сүндерде.* М. Гали. *Төзүче дуслар кул бирәләр Цемент сылап минем кулыма.* Ш. Маннур.

3. Ярык-тишекне: берәр үзле нәрсә белән томалап каплау, бетерү. *Мич ярыгын сылап кую.* □ *— Егетләрне кирпеч җекләрен сыларга өйрәттем.* А. Гыйләҗев.— *Өммегөлсемгә әйт, моржасының корымын*

ешрак чистартып торсын. Балчыкны да кызганмасын, --- төтен юллыгындагы тишекләрне яхшылап сыласын. Г. Әпсәләмов. || Берәр үзле нәрсә белән тоташтан каплау (стенаны һ. б. ш. жирне). *Саман келәтне кызыл балчык белән сылап агарту. Кыш кергәндә сарайны сылау.* □ *Тизәк белән сылаган читән стена буендагы туры атка борылдык.* М. Әмир. *Акшар белән сылап агартылган Ыспай өйләр монда күбесе.* Ш. Мөдәррис.

4. Кул белән сыпыра-сыпыра һәм басып ышкый-ышкый, махсус дәвалау. *Аякны кырмыска мае белән сылау. Билне сылау.* □ [*Хатыны*] *Вәли абзыйны дәвалап йөрде; аның әчен, аркасын сылады.* Ә. Фәйзи.— *Спирт бу. Бик сызлаган чакларында аяк сыларга дип тотам.* А. Гыйләҗев.

5. *күч. гади с.* Гадәттә начар, яраксыз нәрсәне: табыш-файда белән берәүгә сату яки, бүтәнчә бирептапшырып, аннан котылу.— *Тире җыючы Сәлмән картка мин моны кырык тапкыр алып бардым инде. Көя төшкән, алмыйм ди дә җибәрә, хәтеруш. Тагын бер сыларга тырышып карыйм әле. Бәхет булса, белмәссең...* Г. Мөхәммәтшин. *Кусия ханым, иреннән яшереп кенә, --- теге я бу әйберсен, төсен яки бизәген яратмаган булып, бер-ике йөз файда белән берәрсенә сылап та куйгалый.* Ә. Еники. || Тәрбияндәге, карамагындагы яки кул астындагы кешене: икенче берәү карамагына-кулына тапшырып, аннан арыну-котылу. *Зирәк, бик тырыш бу егеткә Зарифҗан бай үзенең гарип кызын сылаган.* Г. Гобәй.

6. *күч. гади с.* Сугып һ. б. ш. рәвештә берәр җиргә егу. *Таза көрәшче ул: чыкканын берсен күтәреп сылап кына тора.* Сөйләмнән. || Ыргытып бәрү. [*Гәрәй*] *шешәләрне алып җиргә сылады.* А. Гыйләҗев. || Сугу, кыйнау.— *Кызган кунак озын сөйләп тормады, Шешә белән яңак төпкә сылады.* Г. Афзал.

СЫЛАУ II *и.* Берәр ярык-тишеккә яки өслеккә сылап ябыштырган нәрсә, катлам. *Мич кырыкмаса-кырык җирдән сыланып беткән, ләкин күптән сыланган, һәрбер сылау өстенә калын корым утырган иде.* Г. Гобәй.

СЫЛАУ-СЫЙПАУ *ф.* **1.** Иркәләп сыйпау. *Сылап-сыйпап, ялыннан, тамак астыннан иркәләп, аның [яшь айгырның] башына озын, калын тезгенле каеш нуктаны кидерделәр.* Г. Ибраһимов. || *күч.* Берәүнең көенә генә тору, юату яки бик иркәләү.— *Ләләне үз уңаена күп сыпырдык инде, җитәр! Ходайдан булып, эзгә төшсә — бик яхшы; булмый икән, гел сылап-сыйпап кына торып булмас инде.* М. Фәйзи.

2. *күч.* Гаеп, кимчелек һ. б. нәрсәне киметеп күрсәтергә, яшереп-йомып калдырырга тырышу. *Докладта җитешсез якларны сылап-сыйпап уздыру.* □ *— Кайбер кешеләргә карата тиешле чара күрмисең, гаепләрен сылап-сыйпап калдырасың.* Р. Ишморат.

СЫЛТАУ I *ф.* **1.** Берәү эшләгән дип күрсәтү, расларга маташу, шуңа тагу (ачылмаган жинаятьне, исбатланмаган гаепне һ. б. ш.). *Идәннең чүпләнүен бала-чагага сылтау. Гаебен бүтәннәргә сылтап котылырга маташучы.* □ *Мондый хәлләр чыннан да булганнармы, әллә бер наяны --- юри генә Миңнуллага сылтаганмы, ничек булса да булгандыр, тик Миңнулланың әкәмәтрәк кеше дигән даны чыгып калган.* И. Гази.

2. Берәр сәбәпкә, гадәттә урынсыз рәвештә, кайтарып калдыру (җитешсезлекне-кимчелекне). *Эшкә соңга калуны сәгать дөрес йөрмәүгә сылтау.* □ *Эшнең начар булуын яки дөрес бармавын аз белемлеккә генә сылтап калдырып булмый.* С. Рафиков. *Ул һаман мондый тигезсезлекне „тәкъдир"гә сылтый.* Г. Нигъмәти.

СЫЛТАУ II *и.* Гадәттә аклану яки бәйләнү-һөҗүм итү өчен китерелә торган нигезсез, формаль сәбәп. *Бәйләнергә сылтау эзләү.* □ *Ул төплерәк сылтаулар табып, анда [җитәкчеләр курсына] китмәскә дә ниятләп тора иде.* Э. Касыймов. *Хатын, бала эшкә күнексен сылтавы белән, Разияне һич аямыйча эшләтә.* А. Расих.

СЫЛУ *с.* Чибәр, матур. *Сылу кыз. Сылу йөз. Сылу гәүдә.* □ *Синең кебек таза, зифа буйлы, сылу егетне [армиягә] алмый калдырачак түгелләр.* А. Шамов. *Яшь чак — сылу чак.* Р. Ишморат. *Каеннар үзләре шундый нәфис, шундый сылу, шундый зифа, аларны кочып үбәсе килә.* Г. Әпсәләмов.

СЫЛУЛАНУ *ф.* Сылуга әйләнү, матурлану, чибәрләнү. *Әнисә унөч яшендә генә булса да, буйга миннән бик үк калышмый. Ул үскән саен сылулана, тыйнаклана бара.* З. Бәширн. *Бүген ул Мәдинә өчен — буйга җитеп сылуланган матур кызы өчен чынчыннан куркып хәвефләнде.* Г. Минский.

СЫЛУЛЫК *и.* Сылу булу сыйфаты; матурлык, чибәрлек. *Мыек дигәннән, Нургали йөз сылулыгының бу яңа бизәген фронттан алып кайткан иде.* Ә. Еники. *Сылу, сылу диләр иде, Сылулыгы чын, имеш.* Җыр.

СЫМАК *бәйл., кис. сөйл. к.* сыман. *Бәләкәй генә лапас сымак җиргә Мәхмүт атын тугарды.* Ш. Маннур. *Карчык белән Газизә аңа гажәпләнгән сымак көлемсерәп карадылар.* Ш. Камал.

СЫМАН *бәйл., кис.* **1.** *бәйл.* Охшату-чагыштыруны белдереп, „кебегрәк, төслерәк, рәвешлерәк" дигәнне аңлата. *Дага сыман тимер. Атау сыман җир. Су сыман матдә.* □ *Чайкалды алтын басулар, Киң сулап диңгез сыман.* Ә. Исхак.

2. *кис.* Эш-хәлне, хәрәкәтне, сыйфатны һ. б. ш. белдергән сүзләрдән соң: шулай тоелуны аңлата. *Бер хис әйдәп бара сыман, Бер тылсымлы уй башта.* Ә. Юныс. *Ишек аллары томан. Шул томанның арасында Сез дусларым бар сыман.* Җыр. *Ул үзенең яшенә карата олырак сыман иде.* С. Рафиков.

СЫН *и.* **1.** Кешегә яки башка җан иясенә охшатып эшләнгән скульптура әсәре. *Таш сын.* □ *Язу өстәлендә Ленинның оста кул белән бронзадан эшләнгән кечерәк кенә бер бюсты күренә. Тагын бер кырыйда — кара көмештән коелган мәһабәт бер Ләчын сыны.* Г. Бәширов. *Бакчаның урта бер җирендә --- тәбәнәк кенә сын тора.* С. Сабиров.

2. Кешегә яки башка җан иясенә охшатып ясалган рәсем. *Рәсемгә күбрәк үземнең уенчыкларга карап, өй, мәчет, пароход сурәтләрен төшерәм. Кай чагында ат, сыер, кеше сыннарын да ясап куям.* З. Бәширн.

3. Гәүдә (кешедә). *Сынны турайту. Төз сын. Зифа сын.* □ *Ул [көрәшче] Фазылны кысып алырга теләп, сөлгене тартты. Фазыл, сынын катырып, билен бирмәде.* Ә. Фәйзи. *Бүген кызның сыны егеткә тагы да күреклерәк, тагы да зифарак булып күренде.* К. Тинчурин.

4. Мәҗүси һәм кайбер дини халыкларда: скульптура яки рәсем итеп ясалган, табына торган нәрсә. *Будда сыны. Чиркәүдәге сыннар. Сыннарга табыну.*

◇ **Сын кату** — бер әгъзаны да кыймылдата алмас хәлгә килеп, хәрәкәтсез калу. *Мондый каты газапны беренче мәртәбә татучы Илсөярнең сыны катты, минутка якын тын ала алмыйча ятты ул.* Г. Гобәй.

СЫНАЛГАН *с.* Берәр эштә-хәлдә сынауны үткән, яраклылыгы-сәләтлелеге күренгән; тәжрибәле, ышанычлы.— *Ул инде бездә сыналган ат, күрше авыл тумасы, аны карап та торасы юк.* М. Гали.— *Ул минем сыналган кешем.* Т. Гыйззәт.

СЫНАЛУ *ф. Төш. юн. к.* сынау I. || Нинди, нәрсәгә сәләтле-яраклы икәнлек беленү, күренү. *Батыр яуда сынала.* Мәкаль. *Матур уйлар эштә сынала.* Ш. Мөдәррис.

СЫНАТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* сынау I.

2. *күч.* Берәр нәрсәне булдыра алмыйча, уңайсыз хәлгә калу; бирешү, җиңелү. *Сынатмадым, тырыш хезмәт белән Ярты гомер юлы үтелде.* З. Мансур. *Егет сината. Секундлар белән исәпләнә торган хәлиткеч бер моментта каушап кала.* Г. Иделле. *— Егет бул, шул кыз алдында сынатып торма, эре генә чык та кит.* Ә. Фәйзи. || Өметне, ышанычны аклamау; файдаланганда яраксыз булып чыгу. *Җирән кашка нишли, тегелә, сынатмадымы?* Ш. Камал. *Ә күз малайларның берсенең дә сината торган түгел.* Г. Гобәй.

СЫНАУ I *ф.* **1.** Берәр нәрсәнең яраклылык, кыйммәтлелек дәрәҗәсен, сыйфатын тикшереп карау, билгеләү.— *Яңа тип машина сыныйсы бар.* Т. Гыйззәт. [*Очучы:*] *Моторны җирдә сынавымны үтенделәр.* С. Баттал.— [*Яңа даруның*] *кеше организмына ничек тәэсир иткәнен, куркынычлы түгелме икәнлеген сынарга да вакыт җитте кебек. Беренче чиратта, әлбәттә, үземдә сынап карамакчы булам.* Х. Вахит. || Берәр нәрсәнең яки кешенең уңай-кире сыйфатларын белү өчен күзәтү. *Кунак әз утырыр, күп сынар.* Мәкаль. *Гакылын-фигылен сынамыйча, алданмагыз матурга.* Г. Тукай. *Еллар минем күңел сафлыгымны Утка-суга салып сынады.* Ф. Кәрим. *Сез кемнәр дип сорамагыз, Эш өстендә сынагыз.* Ә. Ерикәй. || Тормышында-эшендә кичереп, шәхси тәҗрибәңнән белү. *Нургалинең мондый хәлне практикада сынаганы бар.* Ә. Еники.

2. Көчне, белемне, сәләтне һ. б. ш.: кулланып карау. *Дошманыннан җиңелмәс, сер бирмәс өчен, Иске авыл сынап карый барлык көчен.* М. Гафури.— *Я, хәзер син сәләтеңне сынап кара, егетем.* Г. Әпсәләмов.

СЫНАУ II *и.* **1.** Уку йортларында: белем дәрәҗәсен тикшереп, рәсми бәяләү эше; имтихан. *Язма сынау. Сынау алучы. Көзге сынауга калу. Сынау билетлары. Сынау комиссиясе.* □ *Сынауларың биргәч, аңбашыннан Тау төшкәндәй булып тоела.* М. Хөсәен.

2. Эшләнгән нәрсәнең яраклылык дәрәҗәсен, сыйфатын бәяләү өчен үткәрелә-оештырыла торган рәсми тикшерү; эшләтеп, файдаланып карау эше. *Яңа машинаның сынауда булу срогы.* □ *— Җәнлекләрдә шактый сынау үткәрдем. Хәзер инде препаратның кеше организмына ничек тәэсир иткәнен --- сынарга да вакыт җитте.* Х. Вахит. *Кабул итү сынаулары вакытында яңа теплоходны бик җентекләп өйрәнде* [*капитан*]. С. Сабиров.

3. *күч.* Тормыштагы, эштәге кыенлык; авыр хәл. *Сугыш елы сынаулары. Баштан күп сынаулар үтү.* □ *Куркытмыйлар безне нинди сынаулар да.* Ә. Исхак. *Тормышның һәр сынавы кеше өчен бушка гына үтми.* Ә. Еники. *Без үтмәгән юл калмады, Авыр сынауларда түздек без.* Ә. Ерикәй.

СЫНАУЛЫ *с.* Бик җентекле, бик күзәтеп-сынап карый торган (караш турында). [*Укытучы*] *укучыларга үткен һәм сынаулы караш белән карый.* А. Әхмәт.

СЫНАУЧЫ *и. махс.* Төрле машиналарны, аппаратларны, материалларны сынау белгече. *Мин сынаучыны көтәм. Иртәгә* [*очкычны*] *сынау вакытында очу режимнары турында --- сөйләшеп куярга иде.* С. Баттал.

СЫНАШ **1.** „Сынашу“ фигыленнән ясалган исем. *Совет иленда --- яшьләр өчен эш, ярыш, көч сынаш мәйданының тар булганы юк.* М. Максуд. || Зур көч куюны, осталыкны сорый торган авыр эш, сынау. *Утау артыннан тагы печән җыюлар, кибән салулар килде, аннан арыш урагына төштеләр. Бу — Гөлбану өчен икенче сынаш иде, ләкин сер бирмәде.* Г. Ибраһимов.

2. *юг.* Ярыш, көрәш. *Сынашларда билең түзәрме?* Ф. Бурнаш.

СЫНАШУ *ф.* **1.** *Урт. юн. к.* сынау I.

2. *күч.* Ярышу, көрәшү.— *Ниятең булса, апай, Җырлашып карыйк давай. Синме, минме өскә чыгар, Сынашып карыйк, малай!* Һ. Такташ.— *Авылда үзеңнең яратып йөргән кызларың да, басуга чыккач, җир өстендә сынашырбыз без аның белән, дип әйтәләр икән ди.* М. Гали.

СЫНДЫРУ *ф.* 1. Берәр озынча әйберне һ. б. ш. нәрсәне: көч белән бөгеп, бәреп-сугып аркылыга чатнату. *Фәритнең этисе, самолеты яна башлагач, парашют белән сикереп кулын сындырган.* Г. Гобәй. || Шул рәвешле каерып ике яки берничә кисәккә аеру, өзү. *Килен, мич башыннан чыра алып, таза куллары белән аны берничәгә шартлатып сындырды.* А. Шамов. *Егоров сандыкка атланып утырды һәм, бер балыкны урталай сындырып, ашый да башлады.* И. Гази. || Берәр нәрсәне шул рәвешчә өзеп, аерып җыю, хәзерләү. *Аска ылыс сындырып җәю.* □ *Әдһәм бер агачтан корган чыбыкларны сындыра.* М. Фәйзи. || Үсемлекләрне-куакларны: төрлечә таптап, каерып яки бүтәнчә имгәтеп бетерү. *Печәнне таптыйсыз, куакларны сындырасыз дигән булып, безне Көмешле күл тирәсенә җибәрмиләр иде.* Г. Гали.

2. *күч.* Буйсынырга, килешергә мәҗбүр итү. *Карт белән килен икесе куллап аның [Айдарның] чабуына ябышырга, аны йортта ничек булса да озаграк тотарга --- бик тырышып карасалар да, бу юлы берничек тә сындыра алмадылар.* Ф. Хөсни. *Әйе, корыч сына, ләкин Искәндәрне сындыра алмадылар.* Г. Гобәй. || Җиңү, бетерү (каршылыкны һ. б. ш. көчне). *Берәүнең икеләнүен сындыру.* □ [*Жандарм:*] *Куркыныч кеше булганлыктан түгел, кирелегеңне сындыру өчен генә кулга алдык.* К. Нәҗми.— *Бу тауларның каршылыгын сындырырбыз, серен ачарбыз дип ышанам.* А. Әхмәт. || Хәлләр белән килешергә мәҗбүр итү, төшенкелеккә дучар итү (төрле авырлыклар, кайгы-хәсрәт һ. б. турында). *Шатлык рухландыра, ләкин кайгы да кешене сындырмый.* Г. Иделле.

3. *күч. з-сыз да кулланыла.* Кинәт җылытып җибәрү, салкынлыгы кискен кимү (кышкы көн, һава турында). *Көн чыннан да шактый нык сындырган, кояшның да кичәге кебек колаклары тырпаеп тормый.* А. Гыйләҗев. *Җил тыныч, баягы ачы суык бераз сындырды.* С. Әдһәмова. *Талипның эченә җылы йөгерде. Сындырачак болай булгач [көн җылыту билгеләре күренә башлагач], чыннап торып йомшартачак.* Каз. утл.

4. *күч. гади с.* Эчү (шешәле аракыны һ. б. ш. эчемлекне).— *Кая, морза, баш авырта, яртыны сындырыйм әле.* Г. Камал.— *Ярый, сау бул, Шәрифулла; Сагындырма, Ялындырма Кагылырга иртә-кичен: Сындырырбыз мөгәричен!* Г. Афзал.

СЫНЛЫ *с.* Өстендә сын (1, 2 мәгъ.) булган, сын белән бизәлгән яисә сыннар белән аралаш эшләнгән (бизәүләр-бизәкләр турында). *Сынлы китап. Сынлы бизәк.*

Сынлы сәнгать *махс.* — яссылыктагы яки күләмле (рәсем-фото, скульптура һәм графика) әсәрләр иҗат итү сәнгате. *Сынлы сәнгать музее. Ял паркларын, җәмәгать урыннарын һәм йортларын, стеналарны сынлы сәнгать фигуралары белән бизәү.*

СЫНУ *ф.* **1.** Нык бөгү-каерудан, каты бәрү-бәрелүдән һ. б. ш. көчле һәм кискен тәэсирдән-хәрәкәттән: аркылыга чатнау (гадәттә озынча нәрсәләр турында). *Өрлек, матча, сайгак сыну. Сынмый, бөгелә*

генә торган материал. Тал чыбыгының тимер чыбыктан тизрәк сынуы. Брак детальнең сына башлаган җирен табу. Умыртка, аяк сыну. Сынган кулны гипска салу. Сынган сөяк нең төзәлүе. Кошның җайсыз бәрелеп канаты сыну. □ *Мухинның саксызлыгы аркасында ул атның биле сынган.* А. Шамов. || Шул рәвешле каерылып ике яки берничә кисәккә өзелү, аерылу. *Боз сөңгесенең дүрт-биш кисәккә сынуы. Пычкының урталай сынуы. Давылда агачлар сыну.* || Әйбернең кечерәк өлеше-кисәге турында: шул рәвешле аерылып-өзелеп төшү. *Тарак теше сыну. Инә очы сыну. Чәйнек борынының төптән үк сынып чыгуы.* □ *Талның бер ботагы шартлап сынды да һава сызгыртып җиргә төште.* Каз. утл. || Яшь үлән сабагы, кәгазь бите һ. б. ш. турында: кискен бөкләнү, кырт бөгелү. *Сабагы тиз сынучан үсемлекләр. Суган кыякларының сынуы. Ялгыш бөгәрләнеп аста калган китапның катыргысы сыну.*

2. *күч.* Буйсынырга, килешергә-ризалашырга мәҗбүр булу; рухи җиңелү, бирешү (кеше, аның ихтыяры турында). *Тиз генә сынмый торган, көчле ихтыярлы кешеләр.* □ *Нинаять, байбикә [сәфәргә каршы булса да] сынды. „Тапшырдык, булмаса" диде ул ахыр чиктә. Юл хәстәрен күрергә керештеләр.* М. Хәсәнов. || Бетерелү, бетү (каршылык, кирелек һ. б. ш. турында).

3. *күч.* Кинәт җылынып китү, температурасы кискен күтәрелү (кышкы бик салкын көн, һава турында). *Көн сына, җылынып киткәндәй була.* М. Хәсәнов. || Кинәт йомшау, кискен кимү (каты салкыннар турында). *Салкыннар бераз сына төшкәч Мария Александровна --- Казанга алып китте [балаларын].* Г. Әпсәләмов.

4. *физ.* Бер физик мохиттан икенчесенә күчүче нур, төрле дулкын турында: юнәлешен үзгәртү. *Яктылыкның сынуы. Сыну почмагы.*

СЫНЧЫ *и.* Сын (1, 2 мәгъ.) ясаучы, сынлы сәнгать остасы. *Борынгы сынчылар.*

СЫНЫК *с.* **1.** Сынып, бөтенлеге-төзеклеге беткән: чатлаган, бөгелгән, кителгән һ. б. ш. *Сыныk пәке белән таяк юну. Сөяк нең сыныk урыны хәрәкәтсез торырлык итеп кулны гипслау. Сыныk теш. Малайларның сыныk рәшәткә ярыгыннан үтеп йөрүе. Сыныk папирос.* □ *[Алпавыт ташлап киткән өйдә] тәрәзәләр ватык, ишекләр җимерек, баскычлар сыныk, идәннәр каерылып яталар.* Г. Ибраһимов.

2. *күч.* Төшенке, боек (күңел, кеше турында). *Ятим балаларның күңеле сыныk.* Н. Исәнбәт. *Аның үзенчә баллап, тәмле итеп язган хатлары сыныk, төшенке Зәйнәпкә тәэсир итүендә шөбһә юк иде.* М. Гафури. || Төшенке, боек, кайгылы икәнлекне белдерә-сиздерә, күрсәтә торган (тавыш, аваз турында). *Ул яшь аркылы, сыныk тавышы белән ирена сораулар бирде.* Ә. Фәйзи.

3. *и. мәгъ. гадәттә тартымлы форм.* Берәр әйбердән сындырып алынган яки кителеп-сынып төшкән кисәк яисә шул әйбернең калдыгы. *Тарак сыныгы. Дага сыныгы.* □ *Рөстәм үзенең дус малайларын алачыктагы китек ураклар, чалгы сыныклары белән коралландырып кичке әңгердә пәри кararга барган иде.* К. Нәҗми.

4. *и. мәгъ. гадәттә тартымлы форм.* Сындырып яки кисеп алган ипи һ. б. ш. ашамлык кисәге; кечкенә кисәк ипи, ашамлык. *Бәлеш сыныгы.* □ *Ул башта сумкасыннан алып Акбүзгә кечерәк кенә бер сыныk икмәк ташлады.* Г. Гобәй.

Сыныk сызык *мат.*— үзара почмак ясап тоташучы турылардан торган сызык.

Сыныкка сылтау *ирон.*— 1) үзеңне аклау өчен китерелә торган нигезсез дәлил, формаль сәбәп. *Имеш, яңгыр юк. --- Юк, сыныкка сылтау гына бу; төп сәбәп шунда: иптәш Рәхимҗанов агротехниканы санга сукмый.* Соц. Тат.; 2) берәүгә бәйләнү өчен формаль сәбәп, нигезсез дәлил. *[Яшьләргә] сыныкка сылтау табылып кына тора. Җырларын да бит сайлап кына җырлыйлар.* М. Фәйзи.

СЫНЫКЛЫК *и.* Сыныk (1, 2 мәгъ.) булу сыйфаты, хәле. *Аның бу өметсезләнүе, бу сыныклыгы минем эчемне өзә иде.* Ш. Камал.

СЫНЫК-САНЫК *җыйг. и.* **1.** Төрле нәрсәләрнең сынган-кителгән кисәкләре. *Бу өр-яңа бина янындарак кирпеч сыныk-саныкларыннан тау өеп куелган иде. Сыныk-саныk дигәч тә, бу зур гына өем эчендә эшкә ярардай кирпечләр дә аз күренми иде.* Э. Касыймов.

2. Ипи һәм камыр аш сыныклары, калдык кисәкләре. *Табыннан калган сыныk-саныкны малга бирү.* □ *Бала-чагалы кешенең өендә тычканнарга яланырга сыныk-саныклар табыладыр.* Г. Тукай. *Сөяксанак, сыныk-саныk биш-алты ир кешенең табагыннан бер эткә түгел, биш эткә җитәрлек калды.* Н. Фәттах.

СЫПКЫ *и. диал.* Аяк астындагы сыек пычрак. *Машинабызның күренеше бик үк чибәр түгел, ул тәгәрмәчләреннән кузовынача сыпкыга баткан иде.* Г. Тавлин.

СЫП-СЫЕК *с. Артык. дәр. к.* сыек (1—6 мәгъ.). *Сып-сыек чәй. Сып-сыек томан.* □ *[Чәчәкләрнең] аклыгы өстендә, энҗеләр өстендәге шикелле, сып-сыек зәңгәрсу шәүлә вә ул шәүлә эчендә алсу дулкыннар йөгергән.* Ф. Әмирхан.

СЫП-СЫЛУ *с. сир. Артык. дәр. к.* сылу. *Кызганам, карап торсам читтән килеп, Сып-сылу, япьяшь кенә буйларыңны.* С. Рәмиев.

СЫПТЫРТУ *ф. к.* сыптыру. *Безнең белән көчләләр генә кала, ялкаулар сыптырталар.* А. Гыйләҗев.

СЫПТЫРУ *ф.* **1.** Чыбыркы, чыбык ише нәрсә белән: сугу, кыйнау. *Камчы белән сыптыру. Аркага чыбык белән сыптыру. Атка дилбегә белән сыптыру.* □ *[Маллар], кычкырганны гына ишетмәсәләр, яткан җиреннән бик тиз генә сикереп тора да, йөгереп барып, чыбыркысы белән [көтүче] аларга берәрне сыптырып килә.* М. Гали. *Аны үзенчәрәк бастырырга теләгән бер малайга [ат] койрыгы белән битенә сыптырып җибәрде.* И. Гази.

2. *күч. сөйл.* Гадәттә бер нәрсәгә дә игътибар итмәстән кызу-кызу бару яки йөгерү. *Ул аяк астына карамый-нитми турыга гына сыптыра, аркасында ике көпшәле ау мылтыгы селкенгәләп бара иде.* Г. Ахунов.— *Бик карт түгел әле мин, алай еш авырып та тормыйм. Менә хәзер дә, кышкы салкында мин утыз чакрымны җәяү сыптыра алам,— пычак та булмаччак!* Ә. Еники. || Качып, куркып һ. б. ш. рәвештә берәр җирдән тиз генә китү. *Тузгыта аның [дошманның] бандасын Советның штыклары; Туңдыра кышның салкыны һәм кыздыра туплары. Шуңа күрә сыптыралар Алар тын да алмыйча.* Ә. Исхак. || Куып җибәрүне-җибәрелүне белдерә. *Сыптыр тизрәк!— дип кычкырып җибәрде Гыйльметдин [иптәш малаена].* Г. Иделле.

3. *күч. сөйл.* Талымсыз һәм калдырмыйча ашау-эчү турында. *Ул блиндаж авызында иртәнге ашны сыптырып утыра иде.* Х. Камалов.— *Бабай сыптыра гына, шундый ашый.* Ак юл.— *Коймакны күбрәк сыптыр, бәрәңгенең көче юк аның.* И. Гази.

4. *күч. сөйл.* Берәр нәрсәне: урлап алып китү. *Казаклар --- тревога булу белән, атларына бик ашыгыч атланып, каядыр чыгып чаптылар. Шулай да фатир хуҗаларының затлырак нәрсәләрен сыптырырга онытмадылар.* Каз. утл. *Авыл малайлары да*

аналарының берәр нәрсәсен сыптырып тотылгач: — Кояштыр, алмадым,— диләр, Кояшны якасыннан тотып шаһитлеккә өстериләр. һ. Такташ.

СЫПЫЛУ *ф.* Сүтелә, ычкына башлау (бәйләгән, суккан нәрсәнең җепләре һ. б. ш. турында). *Сыпыла башлаганчы яулыкның читен бөгү. Сүсәреп сыпылу.* □ [*Мәдинә*] *шәле астыннан сыпылып чыккан чәчләре арасына бармакларын батырып, чигәләрен угалап алды.* М. Хәсәнов.

СЫПЫРТУ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* сыпыру (1 мәгъ.). || Сыйпарга-сыпырырга мөмкинлек бирү, юл кую (хайван турында).

2. *күч. сөйл.* Гадәттә бер нәрсәгә дә игътибар итмәстән кызу-кызу бару, йөгерү. *Урта яшьләрдәге бер чувашны --- пар аты белән ялладым да, әйдә сыпырт шушы юл белән дип, Чутый юлын күрсәттем.* З. Бәшири. || Качып, куркып берәр җирдән тиз генә китү.— *Синең моннан сыпыртырга йөргәнеңне белгәнгә күрә генә шулай дидем.* А. Гыйләҗев. [*Десантчы:*] *Сыпырттык, туган! Койрыкка баса кабахәтләр!* Каз. утл. || Куып җибәрү-җибәрелүне белдерә.— *Бетмәс монда синең кебек малай-шалайлар, сыпырт ишек алдыннан!* И. Гази.— *Мә дәфтәреңне, моннан соң андый юк мәсьәләләр белән башымны катырма, сыпырт моннан!* Г. Бакиров.

3. *күч. сөйл.* Эшне: тоташтан һәм җитез эшләп бетереп бару. *Бар эшне дә сыпырта торган килен.*

4. *күч. сөйл.* Талымсыз һәм калдырмыйча ашау-эчү турында. *Юлчылар икесе дә бик ачыккан булганнар, шуңа күрә алларына килгәнне эндәшми-тынмый сыпыртып кына утырганнар.* Г. Бәширов.

5. *күч. сөйл.* Берәр нәрсәне: урлап алып китү.

СЫПЫРУ *ф.* **1.** Берәр нәрсәне тигезләргә, ышкырга теләп, аның өстеннән кулны шудырып, ышкытып узу. *Чәчне артка сыпыру. Ашъяулыкның җыерчыкларын сыпыру.* □ *Сапый абзый, киез итекләрен салганнан соң, читекләрен киеп алды һәм аларның куныч сырларын тигезләп сыпыра-сыпыра сөйләнде.* Ә. Фәйзи. || Шул рәвештә берәр нәрсә өстендәге чүпне һ. б. ш. сөртеп, китәрү. *Егет кулы белән мыекларындагы карларны сыпырып төшерде.* М. Гали. *Кыз җәһәт кенә иелде дә сыер аягы астыннан вак саламны кулы белән сыпырып җыя башлады.* Ә. Еники. *Каюм каушый-каушый такта өстендәге балчыкны сыпырып төшерде.* Г. Гобәй. || Сыйпау. *Гыймран агай бер кулы белән тананың мөгезеннән кысып тотып, икенче кулы белән тамак астын сыпырырга кереште.* Г. Ахунов.

2. *күч.* Чыбыркы, чыбык ише нәрсә белән: сугу, кыйнау. *Насыйр чыбыркы белән [этләрнең] аркаларына сыпыра башлады.* М. Гафури.

3. *күч.* Гадәттә бер нәрсәгә дә игътибар итмәстән кызу-кызу бару яки йөгерү. || Качып, куркып һ. б. ш. рәвештә берәр җирдән тиз генә китү. *Моның теленә эләксәң --- күрсәтер бу күрмәгәнеңне!— дип уйлады Һарун һәм, Тәскирә чынлап торып дуларга тотынганчы, моннан тизрәк сыпыру ягын карады.* Н. Фәттах. || Куып җибәрүне-җибәрелүне белдерә.— *Әле сез китмәдегезмени? Сыпырыгыз моннан!— Якуп атын малайлар өстенә борды.* И. Гази.

4. *күч. сөйл.* Күпләп, калдырмыйча алу. [*Садыйк бай:*] *— Барлык алтын-көмешне сыпырдылар.* Ш. Камал. [*Комиссиягә килүче егетләрнең берсе:*] *Егетләр, башта һәрвакыт шулайрак була ул. Менә күрерсез әле соңга таба ничек сыпыра башлаганнарын. Аягына басып торырлыкның һәммәсен дә ала гына бирерләр* [*сугышка*]. М. Гали.

5. *күч. сөйл.* Талымсызланып һәм калдырмыйча ашау-эчү турында.— *Ну пәрәмәче, малай! Тагын бер егермене сыпырырмын, ахрысы.* К. Тинчурин. *Алар икесенә бер кәстрүл аш сыпырдылар.* Ш. Маннур.

6. *күч. сөйл.* Урлау, урлап алып китү.

7. *күч. сөйл.* Эшне: тоташтан һәм җитез эшләп бетереп бару. [*Урактагы әни*] *ару-талуны белми торган җен шикелле эшли, урталыктан сыпырып бара.* Ш. Маннур.

СЫР I *и.* **1.** Берәр нәрсәнең өстендә, өслегендә калкып я батып тора торган әз-сызык рәвешле чыгынты яки кирт. *Шөреп сырлары туры килмәү. Автомобиль тәгәрмәченең сыры ашалып, шомарып бетү.* □ *Сабынлап юса да, уч сырларына утырган мазут үз урынында калды.* Г. Афзал. || Җыерчык. *Йөздәге сырлар.* □ *Ул әллә ничек авыр итеп сулады, маңгай сырларын, битләрен, сирәк сакалын капшады.* А. Тимергалин.

2. Рәсемдә, бизәү сәнгатендә һәм язуда: артык нечкәләп-бизәкләп эшләнгән сызык, сызыклы элемент. *Нинди гүзәл итеп чиккән икән ул мендәр тышларын! Нинди сыр да нинди төс юк ул бизәкләрдә!* Х. Сарьян.

СЫР II *и.* [*сыйр*] Сөттән махсус эшкәртеп ясалган азык продукты. *Сыр кайнату. Вак-вак телемләп табынга куелган сыр.*

СЫРА *и.* **1.** Йорт квасы. *Эти белән әлеге авылдаш үзләре түргә узып самовар янына утырдылар. Аның малае белән безгә калын гына бер телем калач, бер стакан йорт сырасы тоттырдылар.* Г. Бәширов.

2. Арпа салатыннан ясала торган җиңелчә исерткеч эчемлек. *Казан сырасы. Жигули сырасы. Сыра заводы. Шешәле сыра.* □ *— Әхмәт әфәнде, сез сыра эчә торгансыздыр бит?* Г. Камал.

◇ **Сыра мичкәсе** *ирон.*— сыра күп эчүче, гадәттә юан корсаклы кеше турында. *Бездәге сыра мичкәсе булган байлар шикелле, байлыгы вә акчалылыгына горурланмый иде* [*бабай*]. Г. Тукай.

СЫРАЛЫК *с.* **1.** Сыра кайнату өчен диелгән яки шуңа җитәрлек булган.

2. Сыра сатып алу өчен диелгән яки шуңа җитәрлек булган (акча турында). *Эшләреннән бушаган арада Җамалый абзый:— Бусы сыралык булыр!— дип иске киемнәрне ямый, өр-яңа кебек иткәнче үтүкли дә һәр атнаның якшәмбе базарына сатарга алып чыга иде.* Г. Ибраһимов.

СЫРАХАНӘ *и.* Сыра сатыла һәм эчә торган киҫәт яки буфет.— *Карт башың белән сыраханәгә кереп эчмәсәң ярамагандыр шул.* Т. Гыйззәт. *Анда сугыш, анда сыраханә, Анда бөтен этлек, бөтен шакшылык.* М. Җәлил.

СЫРАЧЫ *и.* Элек: сыра кайнатып, шуның белән сәүдә итүче. *Эти мәрхүм эштән сырачыга керергә ярата иде. Кай вакытта ул шунда йоклап та кала иде.* И. Салахов. || Сыра кайнату, сату эшендә эшләүче.

СЫРГАЛАНУ *ф. сир. к.* боргалану (2 мәгъ.). *Музыка күңелле көйләр уйный, ак кул егетләр ал яңаклы, кара күзле фәрештәләр тирәсендә сырганалар.* Г. Ибраһимов. [*Сандал өстендә чүкелә торган кызган*] *тимер бер сыргаланып, бер бөкрәеп, бер тагын тураеп китә.* Н. Дәүли.

СЫРГАН *с.* Сырып тегелгән, җылы (кием-салым, юрган турында). *Сырган чалбар. Сырган юрган. Сырган калын бишмәт.*

СЫРДЫРУ *ф. Йөкл. юн. к.* сыру I (1, 2 мәгъ.). || Сырырга, сырып тегәргә бирү; сырып эшләтеп алу. *Тегүчедән чалбар сырдырып алу. Юрган сырдыру.*

СЫРЛАН *и.* Орынып узганда, вак чәнечкеле орлыклары киемгә, хайван йонына һ. б. ш. ябышып-эләгеп иярә-сырыша торган чүп үлән; *русчасы:* липучка; шул үсемлекнең орлыгы. *Алаша ашап бетергәнче,*

улак яныннан китмәде [Хәбир]. Аның маңгай чәченә ябышкан сырланнарны чүпләде, бәкәл йоннарына каткан балчыкларны алып ташлады. Г. Галиев. *[Исхак] балакларына сырылган сырланнарны йолкып ташлады.* А. Гыйләҗев.

СЫРЛАНУ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сырлау (1 мәгъ.). 2. Жыерчыкланы. *Сулга карыйсың — бик ерактагы зәңгәрсу офыкка, күк читендәге туңудан җыерчыкланып, сырланып каткан соры болытларга барып тоташкан шул ук кырыс чырайлы салкын дала.* Г. Бәширов. 3. *күч.* Кыланчыкланып назлану. *Кыз бер дә назланмыйча, сырланмыйча аның өстәленә узып, Сәләйман белән сөйләшкән булып, матур күзләрен „кафе"ның бөтен почмакларында йөртә башлады.* К. Тинчурин. *Бүтән чакта сырланып, анысын яратмыйм, моныcын яратмыйм дип утырган Кәлим Сәлимеч --- көйгән бутканы да ялт итеп кенә куйды.* Н. Фәттах.

СЫРЛАУ *ф.* **1.** Сырлы итү; сырлар ясау, төшерү. *Ул пәке алды да, бөтен дөньясын онытып, таяк сырлаган булып маташты.* Л. Ихсанова. *Аның авыз кырыйларыннан ияченә таба тирән генә җыерчыклар салынып төшкән, маңгаен да җыерчыклар сырлаган.* Р. Төхфәтуллин. || *күч.* Матур сырлар-сызыклар төшереп һ. б. ш. бизәкләү. *Чигешне сырлап бетерү.* □ *Талдан тартма ясап бирим, сырын үзең сырларсың.* Җыр. *[Ташчы:] Бу минем таш бизәкләрем, Мәңгелек чәчкә алар. Күр син, йортларны ничек мин Матурлап сырлый алам.* М. Сөндекле. || *күч.* Бизәкләү элементлары катыштырып яки дулкынлы сызыкка охшаганрак юллар белән, гадәттә вак кына итеп язу. *Гарәп хәрефләре белән сырлап куя кую.* □ *[Габдулла хикәяне] бер язды, бер бозды; башлап китә алмыйча, дәфтәр читләрен сырлап, чуарлап бетерде, кош сурәтләре төшерде.* Ә. Фәйзи. *[Җиңелгән шәһәр стенасына] имзамны да куйдым. Идел егете Югалмас дип сырладым.* Б. Камалов. 2. *күч.* Артык бизәкле-бормалы, образлы итеп сөйләү турында.

СЫРЛЫ *с.* Сыры яки сырлары булган. *Сырлы стакан. Сырлы тамга. Сырлы бәләк. Сырлы бизәк.* □ *Сыгылып торган басма такталарында аның [узучының] сырлы, төртекле күн итек эзләре торып калды.* Н. Фәттах. *Югарыда чыгып-чыгып торган сырлы-сырлы зур кызыл ташлар кителеп төшәр төсле иде.* М. Әмир.

СЫРМА *с.* **1.** Сырып теккән, сырган. *Сырма юрган.* □ *[Плендәге] егетнең өстендә таланып беткән кыска тун белән тез күзләре бүселеп чыккан сырма чалбар иде.* Ш. Маннур. *[Әбинең] аягында киез итек, өстендә сырма бишмәт.* Г. Гобәй. 2. *и. мәгъ.* Сырып теккән, кыска җылы өс киеме. *Өслөренә сырмалар гына кигән унбиш разведчик сафка тезелеп басып торалар.* Г. Әпсәләмов. 3. *и. мәгъ.* Матрас. *Аска сырма җәю.*

СЫРПАЛАНУ *ф.* Эт, мәче турында: аяк астында урала-урала, янда ышкына-ышкына иркәләнү. *Песи аның аяк арасына килеп керде, сыенды, сырпаланды.* А. Гыйләҗев. *Хуҗалары янында сырпаланучы актырнаклар, сарбайлар,—бөтен шушы чуар күренеш Гафиятнең күңелен тагын очындырып җибәрде.* И. Гази. || *күч.* Әрсезләнеп назлану-иркәләнү, куштанлану. *Ул әнисе тирәсендә сырпалана, иркәләнә, ә кичләрен аның куенына кереп йоклый.* А. Алиш. || *күч.* Куштанланып ялагайлану. *Директор тирәсендә сырпалану.* □ *—Ул тирече Вәли дигәнегез минем тирәдә сырпаланып карады.* Г. Ибраһимов.

СЫРТ *и.* **1.** Хайваннарда: арка. *Колагын сыртына салып чабучы куян.* □ *Мияулый [мәче], Торгызып сырт йоннарын.* Һ. Такташ. *Ара-тирә --- су уртасында берәр балык сыртын елтыратып чумып куя.* Ә. Еники. *Аның көчле куллары астында атларның сыртлары сыгылды.* Г. Әпсәләмов. || *сөйл.* Кешедә: арка. *[Суктырылудан соң] сырты төзәлеп җиткән кешеләр --- бу карчыкның җеназасына барып, олылап күмделәр.* М. Галәү. *Сырты калкып чыгып торган тар аркалы Миңнур карт читтән караганда кызганыч булып күренә иде.* А. Шамов. 2. Арткы, уч төбенә каршы ягы (кулның, бармакның яки кул киеменең). *Ул ике якка асылынып төшкән ак мыегын кул сырты белән уңга-сулга сыпырып куйды.* Ә. Еники. *Кулларыңа кигән бияләең — Укалы да булсын сыртлары.* Җыр. 3. Йөзнең каршы, кире ягы (гадәттә үткен кораллarда). *Пычак сырты белән шикәр ватy.* □ *Салам селкеп бетергәннәребез тырма сырты белән ындыр табагында җәелеп яткан арышны көшелгә өяргә керешәбез.* М. Гали. 4. Буйга сузылган тау түбәсе. *Юлның уң ягында, яшел сыртын калкытып, озын тау сузылып ята.* И. Гази. *Түр тәрәзәдән урам арьягындагы биек тауның сырты күренә.* Г. Әпсәләмов. || Буйга сузылган калку җир. *Авылдан ике километр ераклыкта сөзәк сырт буйлап тимер юл үтә.* Ә. Еники. || Гомумән, буйга сузылган калку-күтәренке нәрсәнең түбәсе. *Бер дулкын сыртыннан алга сикереп киткәндә, икенчесе бәреп аны [көймәне] артка чигерә, ул тагын алга үрмәли, тагын сыртка күтәрелә, тагын сикерә иде.* Ш. Камал. 5. *с. мәгъ.* Калкып-күтәрелеп тора торган; калкулык, сырт (4 мәгъ.) рәвешендәге. *Сырт җир. Сырт басу.* □ *Яз үзенекен итә. Басуның сырт урыннары инде ачылып беткән.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

◇ **Сырт кабарту** — 1) сыртын дугаландырып, йоннарын тырпайтып, ачулы кыяфәт алу (һөҗүмгә каршы торучы мәче, эт һ. б. ш. турында). *[Песи] идән уртасына чыгып баскан, зур күренергә тырышып сыртын кабарткан, эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган.* А. Алиш. *Эт сыртын, йоннарын кабартты.* Г. Гобәй; 2) ризасызлык-килешмәүчәнлек күрсәтү, ачулану; каршы килү. *Ул үзен тәнкыйтьләгәнгә сыртын бик кабарта.* Р. Төхфәтуллин. **Сырт сындыру** — 1) көрәштә: бик каты егу; хурлыкка калдырырлык итеп жиңү.— *Хәлимнең бәхете инде, узган ел миңа көрәшергә туры килмәде. Юкса мин аның сыртын сындырган булыр идем!* Г. Насрый; 2) сугышта: тәмам тар-мар итеп бетерү. *Басып алучылар армиясенең сыртын сындыру.* **Сырт сынса да сынатмау (сер бирмәү)** — бик кыен булса да, хәленне сиздермәү, сер бирмәү. *Яшеңне сөрт, Мәхмүт, теш кысып түз!.. Сер бирмә син сыртың сынса да!* М. Хөсәен. *Егет кеше янәсе [Мәгъсүм], сырты сынса да сер бирмәскә тырыша.* Р. Ишморат.

СЫРТЛАН *и. зоол.* Үләксә ашаучы, имезүче көньяк ерткычы: саргылт яки соргылт тиресенә карарак буй-буй таплар яисә тимгеллəр төшкән төстәге, кыл кебек каты йонлы, яллы хайван; *русчасы:* гиена.

СЫРТЛАП *рәв.* Бик биек өеп. *Печәнне сыртлап төяү.* □ *Тышта буран эш ясаган, баскыч төбеннән тотынып, кәжә абзарына чаклы сыртлап кар өеп киткән иде.* Ф. Хөсни.

СЫРТЛЫК *и.* Сырт җир. *Елга яры буйлап сузылган сыртлык.*

СЫРУ I *ф.* **1.** Ике катлы тукыманы (мәсәлән, әчлек белән астарны), араларына мамык һ. б. салып, буй-буй эзләр ясап яки шакмаклы итеп тегү; кием-юрган кебек эйберләрне шул рәвешле эшләү. *Кыш кияр өчен чалбар сыру. Бишмәтне мамык белән сыру. Бүрек сыру.* □ *Мамык юрган, башын сырган, ятыр идем*

ябынып. Җыр. *Бу бумажи әчлекне шакмаклап сырмаган, буйга гына сырган икән.* Ш. Маннур. || Ике яки берничә катлаган материалны тыгызлык, ныклык өчен еш ара калдырып тегү. *Итек олтаны сыру.*

2. Төрле матур сырлар, бизәкләр һ. б. ш. белән бизәкләп тегү. *Читек сыру. Түбәтәйне сәйлән белән сыру.*

3. *күч.* Бик күп ямау салу, ямап бетерү.

СЫРУ II *ф.* 1. Берәр урында бик күп булып, гадәттә тезелеп урнашу. *Шомыртны чәчәк сыру.*

2. Күп булып иярү, ябышу (сырлан һ. б. иярүчән-ябышучан вак бөртекле нәрсәләр турында). *Балакны сырлан сыру. Сарыкны тигәнәк сыру. Бүрекне кар сыру.* □ *Иван янына килеп, аның киндер күлмәгенә сырган кылчыкларны чүпләргә керешә* [әбисе]. Каз. утл.

3. *күч.* Берәр нәрсә яки кеше янына ишле булып җыелу, аны чолгап алу. *Балны чебен сыру. Агачны кырмыска сыру.* □ [*Карт*] *келәт ишегеннән килеп чыкты. Аны тавыклар сырып алдылар.* И. Гази. *Дүрт бала Нәбиулланы дүрт яктан сырып: — Әти яныннан кайткан, әти яныннан! — дип шаулашып, сикерешеп алдылар.* А. Әхмәт.

СЫРУЛЫ *с.* Сырып эшләнгән, тегелгән; сырган. *Сырулы бишмәт. Сырулы яка. Сырулы юрган.*

СЫРХАНТАЙ *и. к.* сөрхәнтәй.

СЫРХАУ I *с. диал.* 1. Чирле, авыру. *Шулай какча гына, сырхау гына булса да, гомере буе үз эшен кешегә бирмәс, һәр эшен рәтләп кенә, тәмләп кенә эшләр иде ул.* М. Рафиков. — *Сырхау кешедән эш сорамыйлар, аны дәвалыйлар.* Ш. Камал.

2. *и. мәгъ.* Авыру, чир. *Ат сырхавы. Томау сырхавы.* □ *Аңа ашаган тормау сырхавы эләккән икән.* А. Алиш. [*Сабир — тупас мөгамәләле директор турында:*] *Мин аның сырхавына дәвасын беләм.* Х. Вахит.

СЫРХАУ II *ф. к.* Сырхаулау. *Ана үзенең сырхап киткән бердәнберен ничек караса, Хәлим белән Гөлгенә Шәехтайны* [*атны*] *шулай карады.* Г. Гобәй. [*Карчык*] *якындагы бер авылга сырхап торган кызының хәлен белергә дип киткән иде.* Ф. Хөсни. || Авырту, сызлау. — *Кай җирең сырхый, балам?* Т. Гыйззәт.

СЫРХАУЛАУ *ф. диал.* Чирләү, авыру. — *Аңа ел килешмәде ахрысы, тегеләй, гел сырхаулап йөри.* Ш. Камал. *Ул бик еш сырхаулаган, ләкин бер генә тапкыр да доктормы күрмәгән.* Г. Кутуй.

СЫРХАУЛЫ *с. к.* сырхау I (1 мәгъ.). *Чулпанның кәефсез, аз-маз сырхаулы вакытында да ул* [*Муса*] *кызын шул кадәр тиз тыныч ландыра, тиз йоклата ала, безнең исебез китә иде.* Г. Кашшаф.

СЫРХАУЛЫК *и.* Сырхау булу хәле. *Безнең шәкерткә ригаябезне* [*игътибарлы мөнәсәбәтебезне*] *сизеп, ул да* [*мастер*] *тегенең сырхаулыгына вә начар эшләвенә күз очтан гына карап үтә иде.* Ш. Камал. *Сырхаулыкны җиңеп Михаил эшкә чума.* Каз. утл.

СЫРЫЛУ I *ф. Төш. юн. к.* сыру I.

СЫРЫЛУ II *ф.* 1. Күп булып иярү, ябышу, сырышу (сырлан һ. б. турында). *Сырылучан чәнечкеле үләннәр шинель итәкләребезгә ябышалар.* А. Шамов.

2. *күч.* Әрсезләнеп иярергә, янда булырга тырышу, куштанлану. *Хәйдәрнең як-ягына сырылып, өенә кадәр озатып бару балалар өчен зур куаныч була иде.* Г. Бәширов. — *Әкрәм Мирзасы килеп сырылып сүз башлады.* Г. Толымбай.

СЫРЫНТЫ, СЫРЫНДЫ *и.* 1. Гадәттә бер ягы уемтыклырак сырт сыман булып сырышып өелгән кар; дулкын сырты сыманрак салган көрт. *Сырынтыларның буран вакытында барлыкка килүе. Койма буендагы сырынты.* □ *Калкулык аермачык булып күренә. Аның сырынты ятудан киртләчләнеп торган итәгендә, катып калган дулкыннарны хәтерләтеп, кар өемнәре ята.* М. Хәсәнов. [*Буран*] *капка төпләренә күз ачып йомганчы сырындылар ясый, читән буйларына көртләр өя.* Г. Галиев.

2. *җый.* Өскә, киемгә сырышып ябышкан нәрсәләр (кар, мамык һ. б. ш.). *Итектәге кар сырынтысын себерке белән кагып төшерү. Мамык сырындысын дымлы чүпрәк белән сөртеп алу.*

СЫРЫНТЫЛАП *рәв.* Сырынты (1 мәгъ.) итеп (кар салу, көрт өелү турында). *Төнге буран сырлап-сырынтылап салган көрт өстендә купшы саесканнар йөренә.* Каз. утл.

СЫРЫНУ *ф.* 1. Күп булып ябышып иярү, сыру (сырлан, кар һ. б. ш. турында).

2. *күч.* Берәүнең янында булырга тырышу, ана елышу, куштанлану. *Баланың итәккә сырынып торуы.* □ *Сырынмасын аңа сыйфый дошман.* Н. Баян.

СЫРЫШУ *ф.* 1. Күп булып ябышып иярү, сыру (сырлан, кар, мамык һ. б. ш. турында). *Якага кар сырышу. Балакка туфрак сырышу.* □ *Аның өекбашларына чәчәк тузаны кунып, билчән уралып, бакра сырышып беткән.* Э. Еники. *Машинаның каршы тәрәзәсенә кар шундый күп сырыша, --- чүпрәк белән әледән-әле сөртеп алырга туры килә.* Г. Ахунов. *Мостафаның иреннәренә кадәр тузан сырышкан иде.* Ш. Камал.

2. *күч.* Берәр җиргә, кеше янына ишле булып җыелышу. *Кулларына китапларын тоткан балалар Габденнасыйр белән Габделкаюм утырган өстәл тирәсенә килеп сырыштылар.* М. Гали. *Якуп үз тирәсенә сырышып, йотлыгып тыңлап утыручы кешеләргә ялт-ялт карап алды.* И. Гази.

3. *күч.* Берәү янына әрсезләнеп килү, иярү, сыену, куштанлану. *Евгений әүвәл бераз Лиза белән сөйләшеп барса да, тиз арада Хәят янына сырышты.* Ф. Әмирхан. *Сарбай Сабир янына сырыша.* Г. Газиз. *Ул яшенә йотыла-йотыла этисенә сырышты.* Г. Гобәй.

СЫТКЫ *и.* Тәнгә, тирегә чыга торган вак сызлавык. *Аның тәненә әллә нинди бетчәләр, сыткылар чыкты.* М. Галәү. [*Егетнең*] *Мәдинәне очратасы килә, ә сул битенә, үч иткән кебек, борчак кадәр сыткы чыккан.* Ш. Хөсәенов.

СЫТУ *ф.* 1. Каты кысып, эчендәге сыекчасын (яки сыек эчен) агызып чыгару, изү (күкәйне, җимешне, ярылы нәрсәне һ. б. ш.). *Виноградны сыту. Үтне сыту.* || Күкәйне: кабыгын ватып яки тишеп чи килеш ашамлыкка салу, кушу. [*Нәҗия — әнисенә:*] *Пилмән камырына ничә күкәй сытарга?* Э. Еники.

2. Бармак белән каты басып-кысып, эчендәге үлеген-әренен, сары суын чыгару, агызу (шешнең-чуанның һ. б. ш.). *Чуанны сыту.* □ *Әнисе* [*кызының борын очындагы*] *сыткыны сытарга, эченнән сарысын чыгарырга киңәш бирде.* Г. Иделле.

3. Басып-таптап яки бүтәнчә кысып үтерү, изү (бөҗәкне һ. б. ш.). — *Сыерларның украларын ситабыз.* Т. Гыйззәт. *Без дошманны юк итәбез! Тараканны сыткан кебек!* Х. Вахит.

4. Берәр нәрсәнең өстенә басып, таптап-таптатып, утырып, авыр әйбер куеп яки бүтәнчә кысып ныклап яньчү, изү. *Тракторның юл өстендә калган чиләкне сытып узуы. Авыр әржә төшеп консерв банкаларын сытуы.* || Таптап-таптатып, җимереп бетерү. *Трактор Имәлинең тотылып бетмәгән килеш искергән арт читәнен сытып узды.* М. Әмир. *Туплар гөрселди, бөтен нәрсәне сытып, җимереп үкерә-үкерә танклар йөри.* Г. Бәширов.

5. *күч.* Җиңеп тар-мар итү, юк итү. — *Әбез үзебезне сытып ташлаганны авыз ачып көтеп торырбызмы?* И. Гази. *Фронт өчен кирәк булган барлык нәрсәне*

бирербез. Д сез дошманны кыйнагыз, сытыгыз һәм тизрәк җиңеп кайтыгыз! Каз. утл.

6. *күч.* Йөзне, чырайны: бозу, ямьсезләү (авыртудан, җирәнүдән һ. б.). *Әсфәндияр, хәтере калып еларга башлаган бала төсле, чыраен сытты.* Ш. Камал. *Ул, йөзен сытып, йодрыгы белән күкрәгенә суга башлады.* Г. Әпсәләмов.

СЫТЫК *с.* 1. Сытылган, яньчелгән, изелгән. *Сытык күкәй. Сытык лимон.*

2. *күч.* Бик күңелсез, ямьсез, бозык (йөз, чырай турында). *Нишләтергә инде моны дигәндәй, сытык чырай белән карап торды ул бу кәгазь кисәгенә.* Г. Минский. || Бик кәефсез, еларга гына торучы. *Сытык бала.* □ [*Рәхимә:*] *Үләм, бетерде кулымны!* [*Әнисә:*] *Әй, сытык! Әнә салкын суга тыгып тор. Хәзер бетәр.* Г. Нәбиуллин.

СЫТЫЛУ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* сыту (1—4 мәгъ.).

2. Тишелеп-ертылып, эчендәге сыегы чыга башлау. *Әллә үт куыгы сытылганмы аның?* Х. Вахит. || Тишелеп, эчендәге үлеге, сары суы чыга башлау (шеш, чуан һ. б. ш. турында). [*Зифа:*] *Учларым кабара язды бугай. Ай --- кара әле, Сылу, чынлап та кабарып чыккан.* [*Сылу:*] *Абау, мескен, сытылыр да әчетер инде.* М. Фәйзи.

3. Тапталып-кысылып, яньчелеп бетү. *Үч алырбыз без ул бандитлардан Сытылып калган чәчәк өчен дә!* Э. Исхак. *Аның әйләнә-тирәсендә сытылган, яньчелгән вагоннар, бөгәрләнеп килгән рельслар тырпаеп тора иде.* Г. Бәширов. || Басылып-кысылып, изелү. *Беренче буразнаны ясагач, таралып яткан кара балчык өстенә тезләнеп дымлы туфракны учына йомарлады* [*Гафият*], *бармак араларыннан сытылып чыкты туфрак.* И. Гази.

4. *күч.* Бозылу, ямьсезләну (йөз, чырай турында). *Газинур Сәлимнең чырае сытылуын һәм бүре шикелле каравын бик тиз сизеп алды.* Г. Әпсәләмов.

5. *күч. сөйл.* Бик кәефсезләнә яки елый башлау. *— Әй, бу хатын-кызны әйтәм,— дип куйды* [*Фоат*]. *— Бер сүз әйтер хәл юк, хәзер сытылырга гына торалар.* М. Әмир.— *Әй лә, хәзердән үк сытылырга торган җылакларны ияртеп йөргәнче, үзем генә барам да бөтен җиләкне җыеп бетерәм.* Л. Ихсанова.

СЫЮ *ф.* 1. Урын җитәрлек булып, берәр нәрсәнең эченә, өстенә урнаша алу. *Ун чиләк сыярлык мичкә. Залга сыймау.* □ *Амбарына сыймас ударнигның алган ашлыгы.* М. Җәлил. *Юл буена өч-дүрт кеше сыярлык озын, яшел эскәмия нигытылган.* Ф. Әмирхан. || Тишек, аралык һ. б. ш. аркылы кысылмыйча, тоткарланмыйча үтү, үтә алу. *Бармак сыярлык ярык.* □ *Аның гәүдәсе малай сыйган ярыктан чыга алмады.* Г. Гобәй. *Кырыйлары салам көле белән чуарланып беткән, бер генә чана сыярлык тар юлдан тезелеп киткән атлы йөкләр авыл уртасына килеп җитү белән туктаалалар.* М. Гали.

2. Эче, куышы җитәрлек зур булып, берәр нәрсәгә кидерерлек булу. *Күлмәк сыймый башлау.* □ *— Ләлә, җаным! Мә, башмакларымны киеп кара, аягыңа сыямы?* Д. Аппакова.

3. Берәр җирдә яки кеше янында сыену урыны табу, шунда урнаша алу. *Ни күрсәм дә күргәнмен. ни булса да булган, һәр ничек мин бу семьяга сыймаганмын.* Г. Тукай.

4. Мораль кагыйдәләренә, законга һ. б. нормаларга туры килү, ярашу. *Логикага сыймау. Моральгә сыймый торган эш.* □ *Өй сораган юлчыны борып җибәрү безнең халыкның йоласына сыймый.* Н. Исәнбәт. *Үземнең днисәдән качып йөрүемне әдәпкә сыймаган бер тупаслыкка санап, аны кызгана башладым.* З. Бәширн. [*Шагыйрь — байларга:*] *Әсезнең кылган эшләрегез кай шәригатькә сыядыр?* Ш. Мөхәммәдев.

СЫҢАР *с.* 1. Пар, ягъни икеле булган нәрсәнең берсе. *Сыңар кул белән күрешү. Сыңар итек. Сыңар бияләй. Сыңар күз белән генә карау.* □ *Яшел читек эченнән сыңар балагын чыгарып куйган булгач, мин моның башкода икәнлеген сизеп алдым.* М. Әмир.

2. Бик әзәйтеп-киметеп сүрәтләү образы буларак: бер генә; бердәнбер.— *Мин сезгә сыңар шырпы да бурычка бирәсе кеше түгел.* И. Гази.— *Күрмисеңмени? Авыл тып-тын. Сыңар солдат та юк.* Г. Бәширов.— *Сыңар атым ачлык елда бетте.* Х. Туфан.

3. *и. мәгъ. гадәттә тартымлы форм.* Исемнән яки алмашлыктан соң: „шуның кебек, төсле, ише; шуңа бик тартым, охшаган" дигәнне белдерә.— *Нинди ял ди ул? Ике-өч ай эшләмә, --- кайт та кил ялтырап! Гата сыңары, җык җилкә!* Н. Фәттах.— *Хатыны да ире сыңары булмагае.* Н. Исәнбәт.— *Үзе алай ис китәрлек күренми. Безнең сыңар бер бәндә.* Ф. Хөсни.

СЫҢАРЛЫ-СЫҢАРСЫЗ *с.* Икесе ике ишнең сыңары (мәсәлән, икесе дә бер үк кулныкы булган бияләй яки берсе зур, берсе кечкенә булган ботинка һ. б. ш.). *Бала-чаганың сыңарлы-сыңарсыз итек өстерәп чыгуы. Сыңарлы-сыңарсыз чаңгы.* || *рәв. мәгъ.* Бер иш әйбер сыңары белән икенче ишнекен кушып (кул-аяк киемен кию, чаңгы тагу һ. б. ш. турында). *Кабаланганда бияләйне сыңарлы-сыңарсыз киеп чыгу.*

СЫҢАРСЫЗ *с.* Сыңары (1 мәгъ.) юк, парсыз калган. *Сыңарсыз чиләк. Сыңарсыз оек.*

СЭР *и.* Англиядә, АКШта һәм инглизчә сөйләшүче бүтән илләрдә: ир кешегә ихтирамлап мөрәҗәгать итү сүзе.

СЮЖЕТ *и.* 1. Матур әдәбияттә: әчтәлекнең нигезе, әсәрдә бирелгән вакыйгалар. *Тарихи сюжетка язылган әсәрләр. Гади яки катлаулы сюжет. Либретто сюжеты. Романның сюжетын сөйләп бирү.* □ *Поэманың сюжеты бик мавыктыргыч корылган.* М. Максуд. || Әсәрнең нигезен тәшкил итәрдәй вакыйгалар. *Кызыклы сюжетларны ул куен дәфтәренә яза барган.* Г. Нигъмәти. *Бары бүгенгене Сюжет итеп алам җырыма.* Һ. Такташ.

2. Сынлы сәнгатьтә: сүрәтләү предметы.

СЮЖЕТЛЫ *с.* Нигезендә берәр сюжет булган, сюжетка корылган (әсәр турында). *Илленче елларның икенче яртысыннан лирик поэзиядә яңа сыйфатлар төсмерләнә башлый. --- Сюжетлы шигырьләр күбәя.* Каз. утл. *Г. Камалның башка әсәрләре кебек, „Безнең шәһәрнең серләре" ахыргача сюжетлы әсәр түгел.* М. Гали.

СЮИТА *и.* Берничә мөстәкыйль кисәктән торган музыкаль әсәр. [*Ключарев*] *беренче татар сюитасы („Галиябану" сюитасы) язуда тәжрибәләр ясады.* М. Җәлил.

СЮРПРИЗ *и. кит.* Искәрмәгәндә бирелә торган, көтелмәгән бүләк һ. б. ш. нәрсә. || Искәрмәстән килеп чыккан, көтелмәгән берәр эш-хәл. *Дөрес, башта ук инде Мостафинның [сайлауда] төшеп калу ихтималы зур иде, ләкин бу кадәр җимерелеп төшү күпләр өчен чын мәгънәдә сюрприз булды.* Ә. Еники. [*Губернатор:*] *Без менә биредә сөйләшеп утырабыз. Шул чагында, хода белсен, тагын нинди сюрпризлар хәзерләнә.* К. Нәҗми.

СЮРТУК *и.* Ирләрнең ике якка да сәдәпләнә торган, билле, озын чабулы өске киеме. [*Рамазан*] *картайган, бөкрәйгән, сюртук чабулары салынган иде.* Ш. Камал. *Бакчаның йорттан керә торган кечкенә капкасыннан хәтфә якалы кара сюртуктан, цилиндрдан --- Шаһбаз мирза һәм тагы ике кеше килеп керделәр.* Ә. Фәйзи.

СӘБӘП *и.* **1.** Берәр күренешнең нигезендә ята, аны китереп чыгара торган шарт. *Фаҗиганең сәбәбен эзләү.* □ *Иң югары уңыш бирде Безнең колхоз басуы. Сәбәп булды моңа илнең Тоташ колхозлашуы.* М. Җәлил. *Ул бу хәлнең сәбәпләрен, серләрен эзли башлады.* К. Тинчурин. || Берәр нәрсә эшләүне, берәр хәлне аклый торган нигез, сылтау. *Бәйләнергә сәбәп эзләү.* □ *Бүген әни тагын сөйләшмәкче булып йөргән иде дә, мин әле бер сәбәп, әле бер сәбәп табып качтым.* Ф. Әмирхан. *Ул шагыйрь җанлы кеше. Аның өчен кармак салу бер сәбәп кенә. Ул калкавычына караса карар, карамаса юк.* М. Шабаев.

2. Сәбәпче. [*Егетнең*] *өенә кайтмый йөрүендә әнә шул чибәр кызлар сәбәп түгел микән?* А. Әхмәт.

3. *бәйл. мәгъ.* **сәбәптән.** Шул сәбәп аркасында. *Аның йөзе, күзләре бер туктаусыз көлә; зур, таза гәүдәсе мондый шатлык сәбәбеннән яшьләрчә кузгала.* Г. Ибраһимов. [*Күз*] *җил-яңгырданмы яисә башка берәр сәбәптәнме кызарган иде.* А. Шамов.

◇ **Сәбәбенә керешү (керү)** — берәр нәрсәне кайгырта, аңа ирешүнең чарасын күрә башлау.— *Узең яучы җибәрәм, әтиләреңнән соратам дип вәгъдә кылдың, ә үзең һаман да сәбәпләренә керешмисең.* Г. Камал.

СӘБӘПЛЕ *с.* **1.** Әһәмиятле сәбәбе, нигезе булган; бер дә сәбәпсездән эшләнмәгән.

2. Берәр эш-хәл өчен сәбәпче булган. *Бу хәлнең килеп чыгуына кем сәбәпле?* Сөйләмнән.

3. *бәйл. мәгъ.* Аркасында. *Сәгать дүрт тулу сәбәпле, шәкертләргә таралырга да вакыт җиткән иде.* Ф. Әмирхан. *Әгәр дә берәр крестьян фәкыйрьлек сәбәпле бурычка керсә, гомер буе шул бурычны түләп бетерә алмаслык булды.* Урал.

СӘБӘПЛЕЛЕК *и. филос.* Берсе икенчесенең зарури барлыкка килүенә сәбәп булган объектив күренешләрнең үзара бәйләнеш һәм бәйлелек формасы.

СӘБӘПЧЕ *и.* Берәр эш-хәлнең килеп чыгуына сәбәп, этәргеч булган нәрсә яки кеше. *Урынымнан тормадым, уянуыма сәбәпче булган ят тавышны эзләргә тотындым.* А. Шамов. *Эшне яхшы якка таба борып җибәрергә сәбәпче булган ике зур вакыйга булды.* Ф. Хөсни. *Бу эшкә Мөгълифә генә сәбәпче булды.* Г. Камал. *Тантана сәбәпчеләренә бер-бер артлы бүләкләр һәм котлау сүзләре ява.* Р. Ишморатова.

СӘГАДӘТ *и. иск. кит.* Бәхет. *Балалар — безнең бәхетебез вә сәгадәтебез.* Г. Тукай. [*Бай кызы:*] *Мин Шәрәфнең үз кул көче белән көн иткән тормышын үземә сәгадәт саныйм.* М. Фәйзи. *Ялтырый алда сәгадәт юлларым.* Ш. Фидаи.

СӘГАДӘТЛЕ *с. иск. кит.* Бәхетле. *Әй үтә соң тиз сәгадәтле вакыт!* Ф. Бурнаш. *Аңа киңәшләр бирәләр, хәер-дога, бәхет-тәүфыйк, сәгадәтле тормыш телиләр.* Ф. Хөсни.

СӘГАТЬ *и.* **1.** Тәүлек эчендәге вакытны үлчәү коралы. *Кул сәгате. Алтын сәгать. Сәгатьне дөресләү. Сәгатьне җибәрү. Күкеле сәгать.* □ *Сәгать — тормышның агымын күрсәтүче кечкенә механизм. Вакыт күрсәткеч.* Р. Ишморат. *Стена сәгате уникене сукты.* Ш. Камал.

2. Тәүлекнең егерме дүрттән беренә, алтмыш минутка тигез вакыт үлчәү берәмлеге. *Бер сәгатькә соңга калу. Чирек сәгать. Алты сәгать эшләү.* □ *Бер сәгатькә сузылган докладны бик зур дикъкать белән тыңладылар.* М. Гали.— *Китмә! Яңадан ярты гына сәгать тор!* Ф. Әмирхан.

3. Тәүлек башыннан яки көн уртасыннан исәпләп китерә торган, алтмыш минутлык вакыт үлчәме. *Төнге сәгать бер булу. Көндезге сәгать өчтән соң. Сәгать җидедә эшкә китү.* □ *Фәхри, кара әле! Сәгать ничә? Кичекмәсәк кенә ярар иде!* — *диде Мәрьям.* Г. Ибраһимов.— *Тиз кайтырмын, сәгать унберләрдән калмам.* Ш. Мөхәммәдев.

4. Дәрес, лекция өчен билгеләнгән вакыт арасы, берәмлеге (гадәттә кырык биш минут). *Программадагы темаларга барлыгы йөз сәгать бирелү.* □ *Бер сыныкикмәк белән ике бәрәңге ашап алтышар сәгать дәрес тыңларга туры килгәндә дә мин шат һәм көләч идем.* Г. Кутуй. || Педагогик эш: дәрес, лекция. *Сәгатьләрне уку елы башында бүлү. Институттан сәгатьләр алу. Җыр сәгате.*

5. *Аергыч сүздән соң.* Тәүлекнең берәр вакыты, тирәсе. *Иртәнге сәгать иде. Без күңелле генә итеп, тыныч кына чәй эчәбез.* Н. Дәүли. *Узең генә кичке сәгатьләрдә Гөлләргә су сибә идең син.* Ф. Кәрим. || Берәр нәрсә өчен билгеләнгән вакыт. *Көндезге аш сәгате. Эш сәгатен кимету.* □ *Көнлекчеләр, шаулашып, көлешеп, ял сәгате җиткәнгә шатланышып, көндезге ашка кайтып киттеләр.* А. Шамов. *Төн — йоклар сәгать.* Ш. Бабич. *Сәгатьләрең, Таһир, санаулы, бел.* Ф. Бурнаш. || Җаваплы, хәлиткеч, тантаналы һ. б. ш. вакыт, момент, срок. *Нигә соң ул бу дәһшәтле сәгатьтә анда түгел?* И. Гази. *Казан радиосы бу бөек тантана сәгатьләрен эфир аркылы бөтен дөньяга ишеттерде.* М. Җәлил. *Хатыны да дүрт ел көткән, Кавышу сәгатен теләп.* Ә. Ерикәй.

◇ **Сәгате белән; сәгать эчендә** — бик тиз. *Гайбәт сәгате белән шәһәрне каплый.* Г. Ибраһимов. *Таратып җибәргәч, көтү сәгать эчендә әллә ничә дисәтинә җирне иңләп ала.* М. Гали. **Сәгате-минуты белән** — бик тиз, шунда ук. *Сәгате-минуты белән бу шомлы хәбәр шәһәргә таралды.* Г. Ибраһимов. **Сәгать сугу** — 1) берәр эшне эшләргә вакыт җитү, тарихи һ. б. шартлар өлгерү. *Тираннар белеп торсын, бер көнне барыбер үч алу сәгате сугачак.* Р. Ишморат; 2) берәр ижтимагый чор, **тарихи** дәвер һ. б. ш. килү, җитү. *Сукты безнең изге сәгать, Кояш чыкты нурланып. Шатлык җырларын бүген без Җырлыйбыз горурланып.* Ә. Ерикәй; **3) яшәү чоры** бетү, һәлак булу, һәлакәткә дучар ителү. *Әбүбәкер абзый әйтмешли, Фатихка да җәтмә табылган... Сәгате суккан, ниһаять.* Э. Касыймов.

СӘГАТЬЛЕ *с.* **1.** Сәгате булган. *Сәгатьле кеше. Сәгатьле бүлмә.*

2. Сәгатьләр белән үлчәнә, исәпләнә торган; нормаланган (эш, андагы вакыт турында). *Язгы чәчүдә сәгатьле график белән эшләү.* □ *Монда сиңа завод түгел, сәгатьле эш түгел.* Н. Фәттах.

СӘГАТЬЛӘП *рәв.* **1.** Бер яки берничә сәгать буена. *Элеккеге, бер туктамый дөньяны туздырып уйнап-көлеп йөри торган җанлы Сәгыйдә урынына бер дә уйнамый-көлми, утырган җиреннән сәгатьләп кузгалмый, моңаеп, чорсызланып тора торган, ярым җанлы гына бер Сәгыйдә калган иде.* Ш. Камал.

2. Сәгатьләр белән билгеләп, шул рәвешчә нормалап. *Сәгатьләп эшләү.* □ — *Эшкә чыгуны сәгатьләп, минутлап куйдылар да әнә, хәзер эшкә җибәрмиләр. Янәсе, мин кырык минут кичегеп килгәнмен.* Р. Ишморат.

СӘГАТЬЛӘ!РЧӘ *рәв.* Күп сәгать буена; озак. *Бер эш яки бер сүзне аңламый, аз гына ялгыш селкенү яки берәр офицерга честь бирергә өлгерә алмый калу кебек эшләр өчен сәгатьләрчә мылтык күтәреп тору кебек җәзалар [булды].* М. Гафури. [*Көзге алдында*] *сәгатьләрчә ләззәтләнә иде [кыз].* Г. Ибраһимов.

СӘГАТЬТӘ *рәв.* Бик тиз, шунда ук. *Ул эшне без сәгатьтә эшләп ташлыйбыз.* Сөйләмнән.

СӘГАТЬЧЕ *и.* Сәгать ясау яки төзәтү остасы, шул эштә эшләүче. *Чистай сәгатьчеләре.* □ — *Әнә*

сәгатьченеке бик җиңел генә, эскәк белән генә эшлисе бит тә, ул [эш] синең күзеңә ярамый бит. М. Гали.

СӘГАТЬЧЕЛЕК *и.* Сәгатьче һөнәре һәм эше, кәсебе. *[Мәскәү сәгатьчеләре] Чистайның егетләрен һәм кызларын нечкә һөнәргә, сәгатьчелек эшенә өйрәтә башладылар.* М. Максуд.

СӘДАКА *и. к.* садака.

СӘДӘП *и.* 1. Киемдә һәм башка тукыма яки күн әйбердә: ике чабуны, якны махсус тишек яки әлмәктән үткәреп, электереп тоту өчен хезмәт итә торган түгәрәк электергеч, яссы төймәчек. *Изү сәдәбе. Мендәр тышына сәдәп тагу. Бишмәт сәдәбе өзелү.* □ *Өстемдәге күлмәгемнең ике сәдәбе артык.* Җыр. *Аның гимнастеркасының җиз сәдәпләре ялтырый.* С. Рафиков.

2. Сәдәпләр, бизәнү әйберләре һ. б. ясауга китә торган ялтыравык материал (бака кабыгы, моллюск кабырчыгы кебек кайбер кабырчыкларның эчке жемелдек-ялтыравык каты катлавы). *Бу — затлы агачтан матур сырлап, чын сәдәпләр белән бизәклап эшләнгән бик нәфис язу өстәле иде.* Г. Гобәй. *Миндә каладан алып кайткан пәке сабы бар, сөягендә шундый кызыллы-яшелле сәдәп, әй, матур, күрсәң — исең китәр.* Ә. Фәйзи.

3. *с. мәгъ.* Сәдәптән (2 мәгъ.) ясалган яки шуны катнаштырып эшләнгән. *Сәдәп саплы пәке.* □ *Тонык фотографиядәге хатын-кызлар төркеме дә һәм алар белән янәшә, сәдәп кабырчыклар белән бизәлгән рам эчендәге Хәсән портреты да җанлы кебек күренәләр.* К. Нәжми.

СӘДӘПЛЕ *с.* 1. Сәдәбе булган, сәдәп белән электереле торган (кием һ. б. турында).

2. Сәдәп белән электереп куелган, сәдәпләнгән. *Анын изүе һәрвакыт сәдәпле була.* Сөйләмнән.

СӘДӘПЛӘҮ *ф.* Сәдәп белән электереп кую. *Изүне сәдәпләү.* □ *Аклы ситсы күлмәгемнең Җиңе тар сәдәпләргә.* Җыр.

СӘДӘПЧЕ *и.* Сәдәп ясаучы яки шуның белән сәүдә-сату итүче.

СӘЕР I *с.* Башка шундый ук нәрсәләр яки кешеләр кебек түгел, гадәттәгечә булмаган, нәрсәседер ят булган, бераз гаҗәпләндерә торган. *Сәер кеше. Сәер эш. Сәер сүз.* □ *Габдулла өчен Мөхәммәтвәли абзыйны Яңа бистә фатирында күрү генә табигый булганга, аны бу Иске бистә йортында яшәүче итеп күрү бик сәер иде.* Ә. Фәйзи. *Бөтен тирә-якта сәер, ят бушлык һәм җансыз тынлык хөкем сөрә иде.* Ә. Еники. *Бу хатың бик, бик сәер синең.* Г. Бәширов.

СӘЕР II: **сәер итү** *иск.* — карап, күзәтеп тору яки йөрү; тамаша итү. *Габделбасыйр күзләре йомык халәттә шактый вакытлар бу матур һәм кәефле күренешне сәер итеп ятты.* Ф. Әмирхан. *[Балага], әлбәттә, күп сәер итү һәм күп вакыт яхшы һавада --- булырга кирәк.* Г. Тукай.

СӘЕРЛЕК *и.* 1. Сәер булу хәле, сыйфаты, рәвеше. *Безнен баракта тагын бер сәер кеше — Җиһангир абый бар иде. Сәер дип, әллә ни сәерлеге дә юк инде аның, шулай да бик үзенчәлекле егет.* Ш. Маннур. *Күрәсең, тамаша залының сәерлеге артистларга гажәп күренә иде.* Г. Әпсәләмов.

2. Сәер эш, кыланыш. *Кызык халык бу шагыйрь дигәнең! Сөйләсәләр, киемнәренә ут кабардай итеп, ялкын сулап сөйлиләр, сәерлек эшләсәләр, эчең катып көләрдәй сәерлекләр эшләп ташлыйлар.* Г. Ахунов.

СӘЕРЛӘНҮ *ф.* 1. Сәергә әйләнү.

2. *к.* сәерсенү. *Ишектән мин күренгәч тә, ул сәерләнеп китте.* Х. Кәрим. *Габдулланың аягында яңа читек күрү белән әллә ничек сәерләнеп китте ул.* Ә. Фәйзи.

СӘЕРСЕНҮ *ф.* Җиңелчә гажәпсенү. *Шәмсия карчык болай вакытсыз килеп кергән кызны бераз сәерсенебрәк, ләкин ачык йөз белән каршы алды.* Ф. Хөсни. *Шәкертләрнең миңа сәерсенеп, бераз читләштереп караулары сизелеп тора иде.* М. Гафури.

СӘЕРЧЕ *и. иск. кит.* Сәер итүче, күзәтеп, карап торучы яки йөрүче. *Шулай да ул контрабандаларга Тик сәерче булып кала алмый.* Н. Исәнбәт. *Тирәягыбызны сәерчеләрнең көймәләре уратып алганнар, ишкәк тавышы да, өн дә чыгармыйча Мәгъзүмәнең тавышын тыңлыйлар.* Ш. Әхмәдиев.

СӘЙЛӘН *и.* 1. Уртасы тишекле вак пыяла төймәчекләр (муенсага, калфакка тезү һ. б. ш. бизәнү өчен кулланыла); шул төймәчекләрнең берсе. *Калфакны ак, кызыл, зәңгәр сәйләннәр белән чигү.* □ *Үләннәргә сәйлән кебек Таң чыклары төшкәннәр.* Ә. Ерикәй.

2. *с. мәгъ.* Сәйләннән ясалган. *Сәйлән муенса.*

СӘЙРАН *и. иск.* 1. *Гадәттә кыек килештә.* Саф һавада ял итеп күңел ачу. *Җәйнең матур бер көнендә Хуҗа дуслары белән сәйранга, ягъни күңел ачарга чыкканнар.* А. Әхмәт. *Олуг бикә кайта сәйраннан.* Т. Гыйззәт. *Аны кинога төшерткәннәр иде. Болында сәйранда йөргән чагында.* Г. Әпсәләмов.

2. *с. мәгъ.* Күңелле, рәхәт, хозур; иркен. *Сәйран болын.* □ *Шул гажәеп тә хозур, сәйран сахраны тамаша кылып барабыз.* Ә. Еники. *[Казахстанның] сәйран далаларын Алыштырды шулай таш таулар. Шул тауларда, ахры, уяндылар Иҗат серен аңлый башлаулар!* Н. Арсланов. *Бар иде арзан заман, сәйран заман.* Ш. Бабич.

◇ **Сәйран итү (кылу)** *кит.* — сәйранда булу, күңел ачып йөрү. *Ояларың белән исәнләшеп Безнең өйне ташлап китәрсең, Яшь бәпкәләр белән рәхәтләнеп Яшь чирәмдә сәйран итәрсең.* Ш. Бабич. *Уттай эш өстендә сәйран кылып йөрде [бу эшлексез].* Ш. Маннур.

СӘЙРАНЛЫК *и.* 1. Күңеллелек, рәхәтлек, хозурлык; сәйран итү, күңел ачу. — *Бер адәм үзенең сәйранлыкта гизгәнене күрсә — мәшьүм [шомлы] төштер; сәфәр чыгар вә күп мәшәкатьләргә гриftар булыр. Сәдака бирмәк тиештер.* Ф. Әмирхан.

2. Сәйран итә, күңел ача торган, рәхәтлек-күңеллелек бирердәй урын.

СӘЙЯР *и. иск. кит.* Ил гизүче, юл йөрүче, сәяхәтче. *[Фирдәүсинең] „Шаһнамә“сен кабул итми шаһлар, Пайтәхетләр, илләр гизсә дә,— Кире кайта арып-алҗып сәйяр. Төшермиләр озак искә дә.* Н. Арсланов.

СӘКЕ *и.* Элекке авыл өенә хас, идәннән ярты метр чамасы күтәртеп җәйгән калын такталардан гыйбарәт утыру-яту урыны (табын итеп тә файдаланылган олы сәке бөтен түрне алып тора, э ян сәке гадәттә бер генә озын тактадан һәм йөзлексез була); шул такталарның берсе. *Сәкегә урын җәю. Сәке астына каз-тавык утырту. Кече як сәкесе. Мунча сәкесе.* □ *Аларның өске өйләре дә эшләнгән: ишектәрәзә, идән-түшәм дигәндәй, бары да әзер. Тик сәке җәймәгән дә морҗа чыгармаган.* Ш. Маннур. *Гөлгенә түти бик матурлап сәкегә табын әзерләде.* М. Гали. || Сәкегә охшатып ясалган бүтән утыру-яту урыны. *Вагон сәкесе.* □ *Казарма эчендәге буйданбуйга сузылган ике катлы сәкеләр өстендә иске киемнәргә төренгән кешеләр йоклый.* К. Нәжми.

СӘКЕЛЕ *с.* Сәкесе булган, сәке белән җиһазланган (өй һ. б. ш. турында). *Сәкеле өй. Сәкеле мунча. Сәкеле казарма.*

СӘКЕЛЕК *с.* Сәке өчен дип билгеләнгән, шуңа яраклы яки җитәрлек булган. *Мунчаны тиз генә*

бетереп алырга кирәк. --- Идәнгә үзебезнең такталар да ярар; ләүкәлек, сәкелек яңа такта алырбыз. М. Фәйзи.

СӘЛАМ, СӘЛӘМ *и.* Дуслык, яхшы теләк һ. б. ш. хисләрне белдереп, күрешкәндә яки кеше (яисә хат) аркылы әйтелә торган сүз.— *Хәерле көн дуслар! — дидем. Ләкин минем бу сәламемә каршы берәү дә җавап бирмәде.* Н. Дәүли. *Фәтхи, сиңа чын күңелдән бик күп сәламнәр җибәрәм.* Ш. Камал. *Дус-ишләргә сәлам! — диде шат, көләч йөз белән Хәйдәр.* Г. Бәширов.

◇ **Сәлам бирү** *к.* сәламләү. *Әссәламегаләйкем! — дип сәлам бирде мужикларның берсе.* Ә. Фәйзи. *Шәйхаттар бабай кызларга ерактан елмаеп сәлам биреп килде.* Г. Гобәй. **Сәлам хат (хаты)** — сәлам әйтеп, исәнлек-саулык турында гына язылган кыска хат. *Сәлам хаты җибәрәм.* Ә. Ерикәй. **Сәламне алу** — сәламгә, исәнләшү сүзенә җавап кайтару. *Шәмгун карт, гадәтенчә, ишекне киң итеп ачкач, әдәп өчен рөхсәт сорап, сәлам биреп керде. Өстәл янындагылар, аның тавышын ишетеп, күтәрелеп карадылар, сәламен алдылар.* А. Шамов.

СӘЛАМЛӘҮ *ф.* Сәлам! Әссәламегаләйкем! кебек сүзләр яки ишарәләр белән мөрәҗәгать итеп исәнләшү, күрешү. *Баш иеп сәламләү.* □ *[Авыл кешеләренең] очраган берсе яңа мөгаллимне ачык кына сәламлиләр иде.* Ш. Камал. *Егет аларны, бераз елмаеп, баш хәрәкәте һәм күз карашы белән сәламләп каршылады.* А. Шамов. *Айсылу аларга кул изи-изи сәламләп калды.* Г. Бәширов. || Тәбрикләү, котлау. *Һәммә тәбрикләргә каршы: — Юк, сез мине сәламләмәгез, мине тәбрик итмәгез!.. Сезгә мин җырламыйм, --- Гөлбикә моңлана... диясем килә иде.* Г. Ибраһимов.

СӘЛАМӘТ *с.* Сау, таза; чирле түгел.— *Безгә сәламәт балалар өчен, сау яшьлек өчен көрәшергә кирәк.* Р. Ишморат. *Сәламәт тәндә — сәламәт җан.* Ә. Еники.

СӘЛАМӘТЛЕК *и.* Саулык, тазалык. *Сәламәтлек хәбәрегезне белеп шат булдык.* Ш. Мөхәммәдев. *Гали зур кеше, Казанда эшли икән, ләкин фронттагы яраларыннан соң сәламәтлеге бик шәптән түгел икән.* Г. Әпсәләмов.

СӘЛАМӘТЛӘНҮ *ф.* Савыгу, тазару. *Өч яшьлек балага да үзенең сәламәтләнүе өчен дару эчерсәң яки тышка яланаяк, яланбаш чыкма дисәң, билгеле, каршы торадыр.* Г. Тукай.

СӘЛАМӘТСЕЗЛӘНҮ *ф.* Саулыкны югалту, чирләп китү.— *Былтыр сәламәтсезләнеп киттем. Нервы авыруыннан кулларым бозылды.* Соц. Тат.

СӘЛПЕРӘЮ *ф.* **1.** Искерә-туза башлау, таушалу һ. б. сәбәпле бераз салынып төшү. *Җиң сәлперәю. Сәлперәйгән җилән.* □ *Аның бар өсте-башы сәлперәйгән, Аркасы да, җилкәсе дә бөкрәйгән.* З. Мансур. *Аның башында саргая башлаган, читләре сәлперәйгән капрон эшләпә.* Каз. утл. || Шинеп салынып төшү (үсемлек турында). *Сәлперәйгән үсентеләр.* □ *Алмагачларның яфраклары сәлперәеп төшкән.* И. Гази. || Гадәттә җыерчыкланып салынкылану, салынып тора башлау (әгъзалар, тән тиресе турында). *Этнең колагы сәлперәеп төшү. Сәлперәйгән ирен.* □ *Ул урта яшьләрне узып баручы мөдирнең кабаклары сәлперәя башлаган күзләренә карады.* Каз. утл.

2. Чирләү, картаю һ. б. сәбәпле хәлсезләнеп зәгыйфьләнү. *Шәймәрдән бабай ул чакта сәлперәйгән карт булмаган әле.* Л. Ихсанова. || *күч.* Төшенкелеккә бирелү, пассивлану, ихтыярсызлану.

СӘЛӘМӘ *с.* **1.** Бик искергән-тузган һәм ертылгалап-тишелгәләп беткән; алама (гадәттә кием турында). *Сәләмә бүрек. Сәләмә бияләй. Сәләмә күлмәк. Сәләмә капчык.* □ *Фабрика ишек алдындагы эшче казармаларыннан һәм шул тирәдәге вак-вак өйләрдән сәләмә өс-башлы, кайберләре чүпрәккә төреп бала күтәргән һәм бала җитәкләгән хатын-кызлар чыгып базарга агылалар.* М. Гали.

2. Сәләмә киемле.— *Матуркай, кил, кулыңны карыйм, бәхетеңне әйтеп бирәм,— дип, зур кара күзле сәләмә хатыннар Газизә апаның чапаның тарткалап бетерделәр.* Ә. Фәйзи. *Йолкынган чәүкәләргә охшаган сәләмә бер төркем халык, карасу җепшек ком өстендә борыннары белән җиргә хәтле иелә-иелә, калын бер аркан тарталар.* Ш. Камал.

3. *и. мәгъ.* Искергән-тузган, ертык-тишек нәрсә. *Ул вакытта аның өстендә мондый сәләмәләр түгел, укалы киемнәр иде.* М. Галәү. *Анда нинди-нидер иске ләгәннәр, кием сәләмәләре аунап ята.* Г. Бәширов. || Искергән-тузган нәрсәнең ертылып-аерылып торган кисәкләре. *Хәерче, сәләмәләре җилфердәп торган иске киемле карт булу өстенә, аксак та иде.* А. Әхмәт. || *тартымлы форм. ирон.* Бик искергән һәм тузган теләсә нәрсә. *Бу арба сәләмәсен ватып ягарга кул бармый иде.* Г. Гобәй. *Землянканың ишек сәләмәсен, Түбәләрен каерып китә [җил].* Ш. Маннур.

СӘЛӘМӘЛЕК *и.* Сәләмә булу рәвеше һәм хәле.

СӘЛӘМӘЛӘНҮ *ф.* **1.** Бик тузып, ертылып, аламаланып бетү; сәләмәгә (1 мәгъ.) әйләнү. *[Алиш] сәләмәләнеп беткән гимнастеркасының култык эче төбеннән, озак казынып, ерак яшерелгән иң кадерле коралын чыгарды: бармак башыдай гына карандаш кисәге иде ул.* Ш. Маннур.

2. Сәләмәгә (2 мәгъ.), сәләмә киемлегә әйләнү. *[Сара:] Агачтан агачка сугылып мин хәлдән тайдым... Мине куркыныч җәнварлар куды... Дә, сәләмәләнеп беткәнмен.* Ф. Бурнаш. *Тоткын балалар элеккегә караганда да сәләмәләнә төшкәннәр, кыйналудан йөзләре, күз төпләре күгәргән иде.* А. Әхмәт.

СӘЛӘТ *и.* **1.** Кешегә тумыштан бирелгән сыйфат: яхшы эшли, башкара, булдыра алу осталыгы. *Тикшеренү сәләте. Оештыру сәләте. Тимер эшенә сәләтең булу. Математик сәләт.* □ *Үзе машинага утырып йөри дә. Гыймайның үз балаларының андый нечкә эшкә сәләте юк диләр.* М. Фәйзи. *Бу рәсемгә художник бөтен изәт көчен, бөтен дәртен, сәләтен салган булса кирәк.* А. Шамов.

2. *сөйл. гадәттә тартымлы форм.* Үзлек, сыйфат. *Бүтән сүз төркемнәренең исем функциясендә килә алу сәләте. Мөстәкыйль сүзнең җөмлә кисәге булып кулланылу сәләте. Суның парга әйләнү сәләте. Ташның ут чыгару сәләте.*

СӘЛӘТЛЕ *с.* Сәләте (1 мәгъ.) булган; яхшы эшли-булдыра алырдай; булдыклы. *Сәләтле укучы. Җырга сәләтле булу.* □ *Аның хәле бик үк начардан түгел, организмы да көрәшкә сәләтлерәк, ә әнисе ашыгыч ярдәмгә мохтаж иде.* Г. Гобәй.

СӘЛӘТЛЕК, СӘЛӘТЛЕЛЕК *и.* Сәләтле булу сыйфаты; сәләт (1 мәгъ.). *Моның өчен аңа бик күп көч куярга, бик зур сәләтлек күрсәтергә туры килде.* Ә. Фәйзи. *Ул үзенең сәләтлелеге белән математик булырга тиеш иде, ләкин бу юл белән китмәде.* А. Расих.

СӘЛӘТСЕЗ *с.* Сәләте (1 мәгъ.), осталыгы булмаган, берәр нәрсәне булдыра алмаучы; булдыксыз. *Сәләтсез бала.* □ *Эшне сәләтсез, булдыксыз генераллар кулына тапшырганлыктан шулай булды дип сөйләделәр [герман сугышындагы солдатлар].* М. Гали.

СӘЛӘТСЕЗЛЕК *и.* Сәләтсез булу сыйфаты; булдыксызлык. *Патша режимы сугыш алып барырга үзенең бөтенләй сәләтсезлеген күрсәтә.* СССР тарихы.

СӘМАВИ *с. иск. кит.* **1.** Күктән иңә торган. *Кайда сәмави яктылык Берлә янган идеалымның Сихерле*

шәүләсе?! һ. Такташ. || Күктәге, галәм күгендәге; шуңа хас. [*Төшендә ожмахта йөрүче:*] *Хурларның әллә нинди йөрәкне өзеп китә торган сәмави вә илаһи тавыш илә җырлауларын һич тәгъриф итеп бетерә алмыйм.* Г. Тукай. || Гомумән, күккә, галәм киңлегенә мөнәсәбәтле. *Сәмави җисемнәр. Сәмави киңлек.*

2. *күч.* Чынбарлыктан аерылган, абстракт; хыялый, буш. *Сине шагыйрь диләрме? Шигырь язмак белән шагыйль* [*шөгыльләнүче*] *диләрме? — Сәмави сүз! --- Кызыкма бу исемгә.* Г. Тукай. [*Изүчеләр хакимлек иткән дөньядан зарланучы шагыйрь:*] *Сөю, вөҗдан, иман, хаклык кебек Матур сүзләр — искән җил генә; Алар — сәмави сүз, күктә алар, Аларны тик сөйли тел генә.* Ш. Бабич.

3. *күч.* Бик матур. *Сәмави күз.* □ [*Шагыйрь — иректән мәхрүм чибәр кызга:*] *Кемгә соң ләззәт синең тавышың, сәмави сүзләрең?* Н. Исәнбәт.

СӘМАВИЛӘШТЕРҮ *ф. иск. кит.* Абстрактлаштыру, чынбарлыктан аерып карау; романтиклаштыру.

СӘМРУГ *и.* **1.** Әкияттә: бик әре һәм көчле, гадәттән тыш тиз оча торган кош. *Бер заман сәмруг очып килгән дә: — Фу! Адәм исе килә! — дип ачуланып якягына каранырга тотынган. Балалары аңа эшнең ничек-ничек булганын, бер кеше килеп еланны үтергәнен сөйләп биргәннәр. Сәмруг дошманы үлгәнгә бик шатланган.* Әкият.

2. *сөйл.* Патша Россиясе гербында: ике башлы бөркет.

◊ **Сәмруг кош** *к.* сәмруг. *Менә, улым, шушы юл белән бар. Бара-бара бер якты җиргә барып чыгарсың. Анда бер зур агач күрерсең. Шуның башында сәмруг кош оя ясаган булыр.* Әкият.

СӘМӘН *и. гади с.* Акча. [*Хакны кимрәк, әйтелгәннән азрак түләү өчен сатучылашучы:*] *Бездә андый сәмән юк, иптәшкәй.* С. Кальметов.— *Әллә сәмән кирәк булдымы?* М. Зарипов.

СӘНГАТЬ *и.* **1.** Иҗтимагый аңның чынбарлыкны нәфис образлар аша чагылдыра торган формасы; дөньяны эстетик танып белү.

2. Иҗади эшчәнлекнең бер төре: чынбарлыкны нәфис образлар аша сурәтләп бирү иҗаты. *Театр сәнгате. Музыка сәнгате. Кино сәнгате.* □ *Шигырь бит ул бик күп көч куеп озак вакытлар эшләү нәтиҗәсендә генә чын сәнгать үрнәге булу дәрәҗәсенә ирешә ала.* Т. Гыйззәт. *Бу бүлмәдә беренче карауда ук игътибарны үзенә тарткан нәрсә — сынлы һәм нәфис сәнгать әсәрләре иде.* Г. Бәширов.

СӘНГАТЬЛЕ *с.* Нәфис, матур, шул өлкәдәге сәнгать таләпләренә туры китерелгән; яхшы сыйфатлы. *Сәнгатьле уку. Сәнгатьле сөйләм.*

СӘНГАТЬЛЕЛЕК *и.* Сәнгатьле булу сыйфаты.

СӘНГАТЬЧЕ *и.* Сәнгатьнең берәр өлкәсендә эшләүче; сәнгать эшлеклесе. *Туфанны сүз сәнгатьчесе булуы ягыннан гына карап тикшеренүгә монда --- аз урын бирелде.* Г. Нигъмәти.

СӘНГАТЬЧӘ *с.* Сәнгать закончалыкларына, таләпләренә җавап бирердәй. *Әсәрнең сәнгатьчә эшләнешенә карау. Сәнгатьчә фараз. Идеяләрнең һәм фикерләрнең сәнгатьчә гәүдәләнеше. Әдәби әсәрнең сәнгатьчә сыйфаты.* □ *Табышмакларның сәнгатьчә төзелешенә күз салганда иң элек аларның ике төрле алымда ижат ителүләрен күрмичә булмый.* Н. Исәнбәт.

СӘНГАТЬЧӘЛЕК *и.* Сәнгатьчә булу сыйфаты. *Стильнең сәнгатьчәлеге. Әсәрнең сәнгатьчәлек дәрәҗәсе.*

СӘНДЕРӘ *и.* **1.** Авыл өендә: түшәмнән ярты метр чамасы түбәнрәк итеп тактадан ясаган ятак; әйберләр кую урыны. [*Мөрит*] *кичке намазларын укыды да сәндерәгә менеп йокларга ятты.* Т. Гыйззәт. *Мендәремне сәндерәгә ыргыттым да* [*мәдрәсәдән*] *үзебезнең өйгә кайтып киттем.* М. Гафури. || Вагон, пароход, казарма һ. б. ш. җирдә: биек итеп ясаган йоклау урыны. *Вагонның югары кат сәндерәсе.* □ *Палубага чыгып саф һава иснәп кердем һәм өске сәндерәгә урын җайлап йокларга яттым.* Н. Фәттах. *Барак эчендәге катлы-катлы сәндерәләр буш иде.* Ш. Маннур.

2. Лапас, сарай ише түшәмсез каралтының түбә астына печән һ. б. ш. мал азыгы саклау өчен түшәлгән такталар, киртәләр. *Бәрәннәргә дигән печәнне сәндерәгә өю. Мунча алды сәндерәсе.* □ *Сикереп тордым да, үземнең бабай белән бергә каравыл өе лапасының сәндерәсендә ятканлыгымны күреп, шатланып киттем.* М. Гали.

3. Каланча кебек корылмаларда: югарыдагы мәйданчык, такта һ. б. ш. түшәп ясалган урын. [*Скважина авариясе вакытында*] *бозлы су верховой сәндерәсенә кадәр күтәрелеп, кешеләрнең өсләренә явып торды.* Ш. Бикчурин.

СӘНДЕРӘЛЕ *с.* Сәндерәсе, сәндерәләре булган; сәндерәләп эшләнгән. *Сәндерәле өй. Сәндерәле вагон. Сәндерәле лапас.*

СӘНДЕРӘЛӘҮ *ф.* Сәндерәле итү. *Лапасны сәндерәләп эшләү.*

СӘНӘ I *кис. к.* сана.

СӘНӘ II *и. иск.* Ел. *Уткән сәнә безнең өчен --- күбрәк кайгылар вә муаффәкыятьсезлекләр бирде. Бу ел эчендә без әллә ни кадәр матур сүзләр сөйләдек, ләкин --- уннан берсен дә эшкә ашыра алмадык.* Ф. Әмирхан.

СӘНӘК *и.* Печән, салам, тирес ише нәрсәләрне әләктереп күтәрү, өю һ. б. өчен булган авыл хуҗалыгы коралы: башы ике, өч яки дүрт җәпле озын сап. *Тимер сәнәк. Көлтә сәнәге. Сәнәк саплау.* □ *Озын саплы сәнәкләр белән кибәннәргә печән бирәләр.* Г. Бәширов. *Курыкма, бернәрсә дә юк,— дим мин аңа һәм үзем печән астына салган ике җәпле сәнәгемне сиздерми генә капшыйм.* А. Шамов.

◊ **Сәнәк күтәрү** — сәнәк белән һөҗүм итү. *Нәрсә дип мин бу эт мужиклар арасына килдем? --- Балта, сәнәк күтәрерләр дә кереп үтererләр!* [*дип уйлады карчык*]. Г. Ибраһимов. **Сәнәккә күтәрү** — сәнәк белән чәнчеп үтерү. *Әле кичә берәү сөйләп торды: — Патшалары мәтәлеп төште инде, хәзер байларын тимер сәнәккә күтәрергә вакыт ди.* И. Гази. **Сәнәктән көрәк булу** *шелт.*— бюрократ, мин-минлекле кеше һ. б. ш. турында: гади халык арасыннан чыгып күтәрелү.— *Юк инде, әнем, сәнәктән көрәк булдың шул.* Т. Гыйззәт.

СӘНӘКЛЕ *с.* **1.** Кулына сәнәк тоткан; сәнәк белән коралланган. *Ул, сәкедән кузгалып идән уртасына басты да үрелә биреп, урамга, анда шаулаган кусәкле, сәнәкле мужиклар ягына карады.* Г. Ибраһимов.

2. Сәнәк белән, шуны тотып эшләнә торган. *Сәнәкле эштә эшләү.*

3. *к.* сәнәкче (2 мәгъ.). *Фронтын айкадым, ачлыгын кичердем, сәнәклеләрнең фетнәсен бастыруда катнаштым.* А. Расих.

СӘНӘКЛЕК *с.* **1.** Сәнәк ясау өчен диелгән; шуңа яраклы булган (агач һ. б. материал турында).— *Кыштан хәзерләп, чатын чатка аерып тарттырып куйган егермеләп сәнәклек агачыбыз бар.* Г. Галиев.

2. *и. мәгъ.* Сәнәккә дигән яки шуңа яраклы булган материал. *Урманнан сәнәклек алып кайту.*

СӘНӘКЧЕ *и.* **1.** Сәнәк белән, сәнәкле эштә эшләүче. *Кибән куючы сәнәкчеләр.*

2. *тар.* Гражданнар сугышы елларындагы Урал-Волга буе һәм Урал арты кулак фетнәсендә катнашучы.

Закир агай сәнәкчеләр үтергән киң җилкәле, таза әткәсен күз алдына китерә. А. Гыйләҗев. *Егерменче елны бу якларда (Төмән-Тобол, Ишим-Тара буйлары) сәнәкчеләр фетнәсе дигән фаҗигале көннәр булып узган.* Ш. Маннур.

СӘП-СӘЕР *с. Артык. дәр. к.* сәер I. [*Әкият укыганда*] *өй эченә моңарчы ишетелмәгән әллә нинди сәп-сәер ят сүзләр сибелә башлый иде.* Г. Бәширов. *Өйгә кайтып керсәм, сәп-сәер хәл: ишек ачып тупсаны атлаганда ук бәбәй тавышы ишетелде, яшь бәбәй тавышы!* Ш. Маннур.

СӘП-СӘЛӘМӘТ *с. Артык. дәр. к.* сәламәт.

СӘРВИ *и. бот.* Кузаклылар семьялыгыннан, күбесенчә декоратив максат белән үстерелә торган, сары чәчәкле куак яки вак агач; *русчасы:* желтая акация. *Сәрви чәчәген бал кортларының бик яратуы. Малайларның сәрви кузагын өзеп сызгыртып йөрүе. Сәрви борчагы. Сәрви яфрагы. Сәрви куаклыгы. Сәрви яфракчыкларының күләгә аз бирүе. Өй артына сәрви агачы утыртту.* □ *Тузан томаны күтәреп көтү кайта. Алда — сәрви куаклары, шомырт, миләш агачлары эченә күмелеп утырган Кырлай.* Ә. Фәйзи.

СӘРВИЛЕК *и.* Сәрви куаклыгы, сәрвиләр (мул) үскән урын. *Ыңдыр артындагы сәрвилек.*

СӘРГАСКӘР *и. иск.* Гаскәр башлыгы. *Рәт-рәт итеп гаскәрен куйгач тезеп һәм дә җиткезгәч аякка торгызып. Шунда сәргаскәр үзенчә бер горур Берлә гаскәргә карап читтә торыр.* Г. Тукай.

СӘРГЕРДАН, СӘРГӘРДАН *с. иск. кит.* Кайгылы, боек, төшенке күңелле (чит җирдә каңгырып йөрүчеләр турында). [*Егет*] *китә бәхет эзләргә. Ул кешедән сорый, бу кешедән сорый — юк! Берәүдән дә юньлебашлы җавап ала алмый, шулай итеп күп заманнар гажиз вә сәргердан булып йөри.* Ш. Камал. *Шомлы хәбәрләргә ышанып Исламгол җиренә күчкән бер катлы аталар гына бөтен малларыннан, барлык балаларыннан аерылып, Кырым, Кавказ таулары арасында күп еллар сәргәрдан булып йөрделәр.* Х. Кәрим.

СӘРДӘ *и. бот.* Урманда үсә торган күпьеллык үлән, гөмбәз сыман булып оешкан вак-вак ак чәчәкле үсемлек; *русчасы:* сныть.

СӘРДӘЛЕ *с.* 1. Сәрдәләр үсә торган. *Сәрдәле алан.* 2. Сәрдә катнашкан. *Сәрдәле печән.* || Сәрдә салып пешерелгән. *Сәрдәле аш.*

СӘРДӘЛЕК *и.* Сәрдә (күп) үсә торган урын.

СӘРКӘТИП, СӘРКАТИП *и. иск. к.* секретарь. *Сәркәтип булу — сәлам хаты язу гына түгел бит, ил йомышын йомышлый белергә кирәк.* Ш. Маннур.

СӘРКӘТИПЛЕК, СӘРКАТИПЛЕК *и. иск. к.* секретарьлык. *Авыруның берникадәр файдасы да булды: өч ай эчендә күп нәрсә укып чыктым. Вә „Әлислах" газетасында сәркәтиплек хезмәтен иттек һәм хәзер дә итәм.* Ф. Әмирхан.

СӘРМАЯ *и. иск.* Берәр нәрсәне башлап-корып җибәрү өчен билгеләнгән акча, төп капитал. *Таныш булыйк,— диде ул. --- Бәлки, ишеткәнсездер Милли шура казначие Хизбулла Кадермәтевне. Касыйм мөселманнарыннан милли фондка сәрмая җыеп кайтып барам әле.* К. Нәҗми. || Гомумән, акча, байлык. *Вакыт — сәрмаядыр, сәрмаяны бушка сарыф — харамдыр.* М. Акъегет.

СӘРХУШ *с.* Исерек, исергән. *Бүген Галиәкбәр агай бик сәрхуш булып кайткан сәбәпле, аягында торырлык хәле калмаган иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Сахраларга чыксам, сәрхуш булам Һәйбәт сачәкләр исенә; Үземне үзем бетереп Ник төшерәм икән исемә?* Җыр.

СӘРХУШЛАНУ, СӘРХУШЛӘНҮ *ф.* Сәрхуш булу, исерү. *Аек килеш булса бер хәл иде әле, сәрхушләнеп чаба бит [мотоциклчы егет].* Ә. Бикчәнтәева. [*Егетләр-яшьләр белән очрашкан*] *кичәдән бераз сәрхушләнеп, шуның өстенә ничектер гадәттәге тынычлыгын җуеп кайткан лыктан ул [яшь хатын] бүген ятарга ашыкмый, дөресрәге ята алмый иде.* Г. Бәширов.

СӘРХУШЛЫК *и.* Сәрхуш булу хәле; исереклек. *Галиәкбәр агай, сәрхушлыгыннан үзен трактирда дип хыял кылып, хәзрәтне дә бер половой дип белде.* Ш. Мөхәммәдев. *Әгәр аны меңләгән кешеләрнең иртәгә киләсе язмышы кинәт уятып җибәрмәгән булса, ихтимал ул да әле бик рәхәтләнеп шул сәрхушлыкта йөргән булыр иде.* Ш. Маннур.

СӘТЫР *и. иск. кит.* Язуда: юл. *Мәкаләнең дә һәр сәтырында көлке булмый.* Г. Тукай.

СӘФӘР I. *и.* Ерак юл, сәяхәт. *Сәфәр хәзерлеге. Ике көнлек сәфәр. Хәерле сәфәр теләү. Сәфәрдән кайту.* □ *Җәләлнең бу сәфәре озак булды.* Г. Ибраһимов. *Атам мин кечкенә чакта, хаҗ сәфәреннән кайткан чакта юлда үлеп, шәһит булган.* Т. Гыйззәт.

◇ **Сәфәр чыгу (китү)** — сәфәргә, юлга чыгу. *Сәфәр китәчәк көнне иртә белән Сәмигулла абзый [юлга аласы чәен кайгыртты].* Ф. Әмирхан.

СӘФӘР II *и.* Ай елында: икенче календарь айның исеме.

СӘФӘРДӘШ *и.* Сәфәрдә бергә булучы иптәш, сәфәрдәге юлдаш. *Очраклы сәфәрдәш.* □ *Самат та сәфәрдәшләре янына килеп басты.— Җитәбез...* Б. Камалов.

СӘФӘРЧЕ *и.* Сәфәрдә йөрүче, юлчы, сәяхәтче. *Юл тау бите буйлап барды да барды. Байтак юл алгач, сәфәрчеләрнең игътибарын тау кашындагы дәү-дәү комташ кантарлары җәлеп итте.* А. Гыйләҗев.

СӘХИФӘ *и. кит.* 1. *иск.* Китап-дәфтәр, газета-журнал һ. б. ш. нәрсәдә: бит. *Китапның беренче сәхифәсе. Сәхифә читендә искәрмәләр язу.* □ [*Җыентыктагы*] *читенрәк сүзләрне аңлатыр өчен, сәхифә төбенә шәрех тә [аңлатма] төшерелде.* Г. Тукай.

2. Газета-журнал, җыентык һ. б. ш. басмада: игътибарны тарта торган, истәлекле һ. б. ш. бит яки бүлек, өлеш. *Газетаның ял номерларындагы әдәби сәхифәләр.* □ *Айга бер тапкыр Себер яңалыкларын күрсәтә торган фото сәхифә дә оештырып җибәрдек [газетада], айга бер тапкыр әдәби сәхифә чыгару мөмкинлеге дә туды.* Ш. Маннур.

3. *күч.* Гомернең, тормышның берәр чоры, шул чордагы хәлләр, күренешләр. *Тарих сәхифәләре. Тормышның яңа сәхифәсен ачу.* □ *Ятим үскән ярлы кызның язмышында әле яңа гына башланган иң якты сәхифәләрнең беренчесе иде бу.* Г. Минский. *Җаббарның һәр сүзе Камиләнең хәятыннан [тормышыннан] яңа сәхифәләр ача бара.* Г. Ибраһимов. || Истәлек. *Безнең чордан килер буынга ул [бөек электр станциясе] Зур сәхифә булып калачак.* С. Урайский.

СӘХНӘ *и.* 1. Театр тамашасы күрсәтелә торган махсус мәйданчык. *Сәхнә ясау. Ачык сәхнә.* □ *Зал тулы халык, баягыча, үзләренең кайда утырганнарын онытып, сәхнәгә йотылганнар.* М. Әмир. *Клуб сәхнәсендә берсе уйнап, икенчесе җырлаганда аларның пар килүенә сокланып бетә алмыйлар.* Г. Бәширов.

2. Театр; театр эше, артист эшчәнлеге. *Колхоз сәхнәсе. Авыл сәхнәсе. Сәхнә әһеле. Сәхнәдән китү. Сәхнә остасы. Сәхнә әсәре.* □ *Ошбу 1916 нчы ел эчендә милли сәхнәбезгә ун яшь тулды.* Ф. Әмирхан. *Ибрайны, сәхнә белән мавыкканын сизеп алып, драмтүгәрәккә тарталар.* Г. Гобәй.

◇ **Сәхнә арты тормышы** — артистларның, театр коллективының эчке, үзләренә генә хас тормышы. **Сәхнәгә кую** — драма әсәрен: башкару, тамаша итеп күрсәтү. *Г. Камал ул [беренче язган] әсәрләрен сәхнәгә куярлык итеп яңадан киңәйтеп яза.* М. Гали. **Сәхнәгә менү** — 1) сәхнәдә уйный, артист булып эшли башлау; чыгыш ясау. *Аның бу тавыш, бу көйләрдән хәбәрсезлек вә бу акцент белән сәхнәгә менүе — бик урынсыз, бик күңелсез бер җөрьәт.* Ф. Әмирхан; 2) сәхнәдә куела башлау (әсәр турында). **Сәхнәгә чыгу** — 1) сәхнәдә роль уйнау, номер башкару. *Хәтерлисеңме, трал-лә-лә дип Фатыйма Ильская бер рольдә сәхнәгә чыга иде.* Г. Кутуй; 2) артистлык эшен башлап җибәрү; 3) сәхнәдә куела башлау (әсәр турында). **Сәхнәдән төшү** — 1) сәхнә эшеннән, театрдан китү; 2) сәхнәдә куелмый башлау (әсәр турында). *Кайбер дәһи операларның либреттолары начар булган өчен сәхнәдән төшерелүе яки яңа либретто язылуы — күз алдындагы фактлар.* М. Җәлил.

СӘХНӘДӘШ *с.* Сәхнәдә-театрда бергә эшләүче, сәхнәдә бергә чыгыш ясаучы. *Зөһрәгә дә, аның сәхнәдәш дусларына да чын артист булып җиткәнче әле бик күп укырга кирәк.* Азат хатын.

СӘХНӘЛӘШТЕРҮ *ф.* **1.** Сәхнә һәм музыка әсәрләрен: сәхнәгә кую, тамаша итеп күрсәтү, башкару. *Комедияне сәхнәләштерүдә режиссерның роле.* □ *Салих Сәйдәшев татар совет музыкасын тудыруда, аның башлангыч оригиналь җыр формасын эшләүдә, музыканы сәхнәләштерүдә аерым урын тота.* М. Җәлил. *Бер операны сәхнәләштерү дә дирижердан бик зур иҗади сәләт һәм оештыру көче таләп итә.* Каз. утл. || Башка төр әдәби әсәрне: сәхнә әсәренә әйләндереп язу, сәхнәгә кую өчен яраклаштыру; сәхнәгә кую. *Романны, поэманы сәхнәләштерү.* □ [*Укучылар*] *Тукайның „Шүрәле“ һәм „Кәҗә белән сарык“ исемле әсәрләрен сәхнәләштерделәр.* Г. Гобәй.

2. Берәр шәхесне, күренешне, хәл-мөнәсәбәтләрне: сәхнә әсәрендә объект итеп алу, күрсәтү. *Уңай һәм кире типларны сәхнәләштерү. Ватан сугышы эпизодларын сәхнәләштерү.*

СӘХРӘ *и.* **1.** Чүл җире, ком даласы. *Алда, ком сәхрәсе артында, янәдән Дон суы ялтырап күренде.* Г. Гобәй. *Ком сәхрәсе бездән шактый ерак бит.* Каз. утл.

2. Бик матур күренешле җәйге табигать: чәчәкле, саф һавалы болын һ. б. ш. [*Әбисе — оныгына:*] *Әйдә аша да, сәхрәдә йөреп кайтырбыз.* Х. Саръян.— *Кабан күле сулда торырга тиеш, Уңда бер киң сәхрә булырга тиеш.* Г. Тукай.

СӘХРӘЛЕК *и. к.* сәхрә (2 мәгъ.).

СӘХТИЯН *и. иск. к.* сафьян.

СӘХӘР *и.* Мөселманнарда: уразада таң атканчы ашый торган иртәнге аш. *Сәхәргә тору. Сәхәр вакыты җитү.* □ *Уразада өмә дигәнең коры сүз генә шул. --- Сәхәрләре шәп булды булуын! --- Сәхәр ашап бетүгә, яшьрәк егетләр чыктык та җиңел кулдан ике арбага икешәр атны җигеп ташладык.* Г. Ибраһимов.

СӘЯСИ *с. иск. к.* политик. *Сәяси белем. Сәяси лозунг. Сәяси программа. Сәяси партия. Сәяси көрәш.* □ *Драматургия массаны сәяси тәрбияләүнең уңайлы төр коралларыннан булып алынырга тиеш.* М. Җәлил. *Дөресен әйтергә кирәк, моңарчы минем, хикәя, шигырь китапларын яратып укысам да, мондый сәяси темаларга язылган әсәрләрне бу кадәр кызыксынып укыганым юк иде.* М. Әмир.

СӘЯСИЛӘНДЕРҮ *ф.* Берәр нәрсәгә политик юнәлеш, сәяси рәвеш, эчтәлек бирү. *Казан хәлләренә килсәк, алар бер килеш баралар. „Әлислах“ акрын гына, әленеп-салынып кына бара. Хәзер форматын үзгәртеп, мәсләген дә [юлын, максатын] сәясиләндерергә карар бирдек, бәлки аннан соң тәртипле бара башлар.* Ф. Әмирхан.

СӘЯСӘТ *и. иск.* Политика.— *Сез уйлыйсыз, бу базардагы сугыш — очраклы хәл? Юк, бу абсолютизмның төп сәясәте, аларга милләтләрне үзара сугыштырырга кирәк.* Ә. Фәйзи.— *Сез ике якны да егып бетермәү сәясәтен тоттыгыз.* М. Фәйзи.

СӘЯСӘТЧЕ *и. иск.* Сәясәт, политика өлкәсендәге әһел; политик эшлекле. *Милли сәясәтче.* □ — *Сәясәтчеләр җөмһүриятнең җилкән бауларын үз кулларында тоталар.* И. Гази.

СӘЯХӘТ *и.* Чит илләрдә, ерак җирләрдә булып дөнья гизү. *Дөнья әйләнә сәяхәт. Сәяхәткә чыгу. Сәяхәттә булу. Ерак сәяхәт.* □ *Су юлы сәяхәтендә күргәннәре, күргәннәреннән алган тәэсире бик бай булды аның.* Г. Минский. *Ул Сахалин утравына сәяхәткә барып кайта.* Г. Нигъмәти.

◇ **Сәяхәт итү** — сәяхәттә йөрү. *Яхшы җәй көннәрендә Кама һәм Агыйдел пароходларында сәяхәт итүче туристлар һәм турист булмаган „простой юлчылар“ да боларны күздән югалтмыйча карап баралар.* Ш. Камал.

СӘЯХӘТНАМӘ *и.* Юлда, сәяхәттә күргәннәрне язган истәлек һ. б. ш. язма; юлъязма. *Сәяхәт итүчеләр һәр нәрсәне күрә, белә, гыйбрәт ала, һәр күргәнен, һәр ишеткәнен яза. Соңыннан аларны тәртипкә куеп, сәяхәтнамә итеп бастыра, мондый сәяхәтнамәне һәркем укый.* Ш. Мөхәммәдев.

СӘЯХӘТЧЕ *и.* Сәяхәттә йөрүче, сәяхәт итүче. *Поездлар, самолетлар булмаган заманда кыю сәяхәтчеләр, караңгы тайга әчләреннән балта белән юл яра-яра, меңәр чакрым җир үткәннәр.* Ә. Маликов.

СӘҮДӘ *и.* Сату-алу эше, кәсебе. *Сәүдә министрлыгы. Икмәк сәүдәсе. Сәүдә хезмәткәре. Сәүдә кәрваны. Тышкы сәүдә. Сәүдә фирмасы.* □ *Йөрми торган акча нәрсә сәүдәдә?!* Г. Тукай.

◇ **Сәүдә итү** — сату-алу эше белән шөгыльләнү. *Ашлык белән сәүдә итү.* □ *Ул күп еллар читтә, рус арасында йөреп сәүдә иткән.* М. Гали.— *Заманчарак сәүдә иткәндә, безнең ул фирманы хәзер ун өлеш зурайтып булыр иде.* Ф. Әмирхан.

СӘҮДӘГӘР *и.* Хосусый сәүдә белән шөгыльләнүче. *Вак сәүдәгәр. Авыл сәүдәгәре.* □ *Иртә берләп кайнамакта бу базар, Кайда баксаң анда тулган сәүдәгәр.* Г. Тукай. *Сәүдәгәргә юлдаш булсаң, малын сөйләр.* М. Гафури.

СӘҮДӘГӘРЛЕК *и.* Сәүдәгәр булу хәле; сәүдәгәр хезмәте, кәсебе. *Хикмәтулла берничә көннән үк Мәскәүдән китеп барды. --- Әллә сәүдәгәрлек ихтыяҗлары бар идеме — ул кадәресен Исмәт белә алмады.* Г. Әпсәләмов.— *Әнең сәүдәгәрлекне, кулаклыкны ничек итеп бетерү юлларын өйрәнеп, укып яткан саң сәүдәгәр булырга уйлап йөрисең?* М. Әмир.

СӘҮДӘЛӘШҮ *ф. сир. к.* сатулашу. *Яртысын акчалата биргач, әлбәттә, үзләренә кул булмаган, үтмәс товарны алмыйлар [сәүдәгәрләр]. Яхшы карап, хакын сәүдәләшеп, үзләренә кирәкле һәм сатыла торган маллардан алалар.* Ш. Мөхәммәдев.

СӘҮДӘЧЕ *и.* Сәүдә белән шөгыльләнүче, шул өлкәдә эшләүче. *Район сәүдәчеләре.* □ *Бөтен авылга бер генә данә дә тимерче, тегүче вә буяучы кебек һөнәр әһелләре вә кибетче кебек сәүдәчеләр юк иде.* Г. Ибраһимов.

СӘҖДӘ *и.* Намазда: башны җиргә ору хәрәкәте. *Ул намаз укырга яратмый, сәҗдәгә бөгелгәнсе килми.*

Г. Ибраһимов. || Дога белән ялварып баш ору. *Бушка китте күп минем Елап кылган сәждәләр.* Һ. Такташ.

◇ **Сәждә итү (кылу)** — 1) тезләнгән хәлдә алга ятып бөгелеп табыну. *Хаҗи, тәһарәт алып, ахшам намазы укырга керешкән иде, буталып бетте. --- Ике генә тапкыр сәждә итәсе урында тугызмы, унмы тапкыр сәждә кылды.* Ш. Камал; 2) *күч. иск. юг.* берәү алдында хөрмәт белән яки түбәнсенеп, буйсынып баш ию. *Мин бай булсам, кулда алтын балдак булса, Приказчиклар сәждә кылып юлда торса, Көләр идем, корсагымны уа-уа, Гакыллы баш мәскәүләрне алдап булса.* М. Укмасый. *Табындым, сәждә кылдым мин сөйгән жәнашның алдында.* Г. Тукай. **Сәждәгә китү** — *к.* сәждә итү (1 мәгъ.). *Сугыш башланганнан бирле аның намазны бөтен күңеле белән бирелеп, дөнья уйларын кыстырмыйча гына укый алганы юк иде. --- Я аның күз алдына үзе эшли торган яшелчә бакчасы килеп баса; --- я сәждәгә киткәндә генә улы Илгизәрнең кибәргә элгән чалбары, аның тишелеп чыккан тез башлары күзенә чалына да, аңа әче поша башлый.* Г. Бәширов.

СӨАЛЬ *и. иск. к.* сорау II (1 мәгъ.). *Аның: — Сине тәрбия итүче, азык жибәреп торучы бармы соң? — дип соравы миңа жавап бирүе авыр булган бер сөаль булып төште.* М. Гафури.

СӨБХАНАЛЛА *ы. иск.* Гаҗәпләнүне, сокланууны белдерә. — *Сөбханалла, кунак бар икән ләбаса.* Р. Ишморат. — *Сөбханалла, бу нинди сүз. Минме ашыйм кеше хакын?* Г. Камал. — *Сез, Садыйк абзый, яшәреп киткәнсез, сөбханалла, күз тимәсен.* — *диде Хөснулла.* Ш. Камал.

СӨЕКЛЕ *с. шигъ.* 1. Бик ярата торган, аеруча кадерле. *Марат хәзер дә семьяда иң сөекле бала.* Г. Гобәй. *Бу сүзләрне сөйләгәч, Габделбасыйрга Диләфрүз тагы да якынрак, тагы да сөеклерәк тоелып китте.* Ф. Әмирхан. || **сөеклем.** Илтифат белән әйтелгән ягымлы мөрәҗәгать сүзе. [*Нәфисә:*] *Сезгә ничә яшь соң, сөеклем?!* [*Раушания:*] *Тиздән ундүрт тула.* Р. Ишморат. [*Врач — сестрага:*] *Бераздан, сөеклем, бераздан. Хәзер аның палатасына барабыз.* А. Шамов.

2. *и. мәгъ.* Сөйгән яр. *Сагындырырлык туган-үскән жире, сөярдәй сөеклесе булган кеше бик бәхетле кеше инде ул.* Г. Бәширов. *Мин чәчәкләр жыйдым сөеклемә, Бәйләм итеп бәйләп китердем.* М. Жәлил.

СӨЕНДЕРҮ *ф.* Шатландыру; сөенүгә сәбәпче булу. [*Кызның хаты*] *Газинурны шатландыра, сөендерә.* Г. Әпсәләмов. *Сөендергән өчен, дуслар, безне Рәхмәт сезгә керсез күңелдән.* Ш. Маннур.

СӨЕНЕЧ *и.* 1. Сөенү хисе; шатлык. *Бу китап миңа әйтеп бетергесез сөенеч, ләззәт бирде.* Г. Кутуй. *Минем эшем Чын сөенеч бирә күңелемә.* Ш. Маннур.

2. Сөенечле, шатлыклы хәбәр. *Илче, Мин килдем, диде, сөенеч илә.* Ш. Бабич. — *Сөенеченә ни бирәсең, Сафихан абзый?* Г. Мөхәммәтшин. — *Галимә әби, сөенеч: улың кайтты!..* Г. Ибраһимов. [*Заһирә — Мәйсәрәгә:*] *Я, ахирәт, сөенечкә ни бирәсең, тиз бул инде, үземнең дә йөрәгем, уф! --- Сөенечне ишеткәч, йөрәгең түгел, бәгырькәйләрең сикерер!* К. Тинчурин. *Хат килгәч, кичен балалары жыелып, сөенеч чәйләре эчелгәч, [әниләре] дөресен әйтеп бирде.* Г. Гобәй.

◇ **Сөенеч алу** — шатлыклы хәбәрне беренче әйтеп, берәүне сөендерү. *Кайсыдыр шул арада йөгереп барып Гаязның хатыныннан сөенеч алып та өлгергән. Ике баласын ияртkән Миңзифа, жилфер-жилфер атлап, ирен каршы алырга килә иде.* И. Гази. [*Әкълимә:*] *Гөләндәм апа, жаным! Баягысы барышлый булса, бусы кайтышлый. Сөенеч алырга кердем.* [*Гөләндәм:*] *Нәрсә өчен ул хәтле сөенеч?* Ф. Хөсни.

СӨЕНЕЧЛЕ *с.* 1. Сөендерә торган, шатлыклы. *Сөенечле хәбәр. Сөенечле хәл. Сөенечле көн.* □ *Киң безнең тормыш юлыбыз, Өметле, сөенечле.* Г. Хуҗи. *Дөнья ямьле, сөенечле, жылы апрель көтәл* Ш. Бабич.

2. Сөенеч-куанычны белдерә, күрсәтә торган. *Яңа әкият белән мин, диде Игнат сөенечле тавыш белән.* Каз. утл.

СӨЕНЧЕ *и. диал. к.* сөенеч.

СӨЕНҮ *ф.* Куану, шатлану. *Иртән торган саен сөенә-сөенә Рәхмәт укыйм туган жиргә мин.* Ә. Еникәй. *Гөлсем апа балалары өчен сөенеп туя алмый.* Г. Гобәй.

СӨЗГЕ *и диал. к.* сөзгеч (2 мәгъ.). *Балыкчылар, зур сөзгеләренең озын саплары югалып беткәнче суга чумдыра-чумдыра, балык аулыйлар.* Г. Ибраһимов.

СӨЗГЕЧ *и.* 1. Төрле сыеклыкларны сөзеп үткәрә торган иләк сыман әйбер, жайланма. *Ул сөзгеч өстенә ике кат марля куеп сөтне сөзде.* А. Гыйләҗев.

2. Балык сөзү коралы. *Менә сөзгечнең тар койрыгы күренде. Ул эчендә кайнаган балыклары белән ялтырап тора иде.* Р. Фәизов.

СӨЗГӘК *с.* Сөзү гадәте булган. *Сөзгәк сыер.*

СӨЗЕМТӘ *и.* Нәтиҗә, йомгак. *Бу — хәлне күзәтә йөреп, көне-төне уйлана торгач килеп туган авыр уйларның сөземтәсе иде.* Г. Бәширов. [*Башлык*] *бугенге тәжрибәдән сөземтәләр ясады.* М. Жәлил.

СӨЗМӘ *и.* Катыкның суын марля яки киндер аша саркытkач калган куе масса, азык. *Гөлбаһар абыстай ярты әбәт чиләге сөзмә чыгарды. Аны да икмәк белән яхшы гына каптылар.* М. Гали. *Газзә түти чәчәкле касә белән Сәйфулла алдына сөзмә дә китереп куйды.* Ә. Еники.

СӨЗӘГӘЮ *ф. к.* сөзәкләнү. *Куе әрәмәлек башланды. Сөзәгәеп килгән яр битенә үскән иде ул. Бер чите суга кереп тора.* Г. Сәгыйдуллин.

СӨЗӘК *с.* Текә түгел, авышлыгы зур түгел. *Ярның сөзәк урыны. Сөзәк тау бите. Сөзәк итеп ябылган түбә. Сөзәк юл. Авыр мичкәне арбага сөзәк кенә итеп сөягән тактадан тәгәрәтеп менгерү.* □ *Күтәрелә моннан сөзәк үрләр, Жилдә шаулый нарат урманы.* С. Урайский.

СӨЗӘКЛЕК *и.* 1. Сөзәк булу сыйфаты, күренеше. 2. Сөзәк җир. *Елгага төшә торган сөзәклеккә килеп житкәч, [егетләр] икесе дә тын калып аска карадылар.* Ш. Бикчурин.

СӨЗӘКЛӘНҮ *ф.* Сөзәккә әйләнү. *Юл сөзәкләнү.* □ *Елга тамагына якынайган саен, --- ярлар сөзәкләнде, тәбәнәкләнде.* Л. Ихсанова. *Сөзәкләнде текә үрләр, Киңәйделәр тар юллар.* Ш. Маннур.

СӨЗҮ I *ф.* Маңгае белән бәрү-төртү, мөгезе белән төртү-чәнчү (хайван турында). *Бозауның бала-чаганы сөзүе. Үгезнең чит кешене сөзүе. Котыртучыларны сөзә торган тәкә.* □ *Авызларына чәнечкеле керпе тиресеннән, кабыктан ясап кечкенә тубал кигезгән яшь бозаулар тиз генә килеп аналарының имчәкләренә башларын төртәләр, жиленнәрен чәнчүгә түзә алмаган аналары, башларын чайкап, аларны сөзеп жибәрәләр.* М. Гали.

◇ **Сөзеп карау** — бик текәлеп карау. *Сәхипнең кыюлыгы юк иде, сөзеп карады, ләкин әйтергә сүз тапмады кыз.* Г. Ибраһимов. *Сестра аңа ара-тирә сокланып, сөзеп карап алудан башка бер төрле дә игътибар итмәде.* А. Шамов.

СӨЗҮ II *ф.* 1. Чүптән, чит катнашмалардан чистарту-арындыру өчен, сөзгеч, иләк, марля кебек вак тишекле әйбер аркылы агызып үткәрү (сыеклыкларны). *Бензинны сөзеп салу. Сөтне сөзү.* || Сөзгеч, иләк, марля кебек вак тишекле әйбер аркылы үткәреп,

аерып калдыру, аерып алу (сыеклыктагы чүпне, чит катнашманы). *Чәй чүбен сөзү. Шулпадагы вак сөякләрне сөзеп ташлау.*

2. Җәтмә, сөзгеч кебек нәрсә белән аулау, тоту (балыкны һәм су җәнлекләрен). *Җәтмә белән балык сөзү.* □ *Малай-шалайның эше бер: көне буе суда. --- Күлмәк җиңнәрен бәйләп маймыч сөзү дә калмый, кысла тотуы да шунда.* М. Шабаев.

СӨЙГӘН *и. тартымлы форм.* Яраткан кеше, сөйгән яр. *Синнән башка сөйгәнем юк, Сине алмый хәлем юк.* Жыр. *Сөйгәнеңә яр булы!* М. Фәйзи. *Сагынып көтәм сине, сөйгәнем!* М. Җәлил.

СӨЙДЕРГЕЧ *и. иск.* Хорафатка ышанучыларча, берәүне яраттыру өчен кулланыла торган им-том чарасы. *Ырымчы карчыкларның сөйдергеч эшләп бирүе. Сөйдергеч догасы.* □ *— Сандугач канаты — сөйдергеч икән! --- Шуның белән егетнең берәр җирен сыйпасаң, ул егет кызны тәкатьсез булып ярата башлый икән.* Г. Бәширов.

СӨЙКЕМЛЕ *с.* Ягымлы, мөлаем; яратып караттыра торган. *Сөйкемле йөз. Сөйкемле тавыш. Сөйкемле күз. Сөйкемле кул.* □ *Бер күрү белән үк күңелеңне үзенә ала торган, үзенә җылы хисләр, ярату, сөю хисләре уяттыра торган сөйкемле кешеләр була.* К. Басыйров. *Урман ул, Сөмбел, шундый сөйкемле, шундый ямьле.* Д. Аппакова. *Аның кыяфәте сөйкемле генә.* К. Тинчурин.

◇ **Сөйкемле сөягең булу** — яраттыра, сөйкемле күрсәтә торган берәр сыйфатың булу. *Җырлап килә көянтәгә асылган чиләкләрең. Ник әйтмисең, бармы әллә сөйкемле сөякләрең?* Р. Гәрәй. **Сөйкемле сөяк** — яраткан яки сөйкемле кеше турында. [*Галия:*] *Үзеңнең сөйкемле сөягеңә тел тидерергә куркасың.* [*Хәйбул абзый:*] *Акыл өйрәтергә башың яшь әле синең! Белдеңме шуны?! Һе, сөйкемле сөяк имеш! --- Имештер, мин үзем яраткан кайбер кешеләрнең интересын гомуми интерестан алгарак куям.* Р. Ишморат.

СӨЙКЕМЛЕЛЕК *и.* Сөйкемле булу сыйфаты, хәле. *Чырайның сөйкемлелеге. Тавышына сөйкемлелек бирү.* □ *Аның аякларын балаларча бөкләп йомарланып йоклавында, әкрен, тыныч сулу алуында үзенә күрә бер ягымлылык, сөйкемлелек бар иде.* А. Шамов.

СӨЙКЕМЛЕЛӘНҮ *ф.* Сөйкемлегә әйләнү. *Баланың арык тәне алсуланып, йөзе тагын да сөйкемлеләнеп китте* [*юындыргач*]. Г. Гобәй. *— Исәнмесез, — диде ул* [*кыз*] *ягымлы елмаеп һәм шунда ук бөтенләй үзгәреп, сөйкемлеләнеп китте.* М. Шабаев.

СӨЙКЕМСЕЗ *с.* Сөйкемле түгел, күңелгә ошамый торган. *Сөйкемсез чырайлы кеше. Сөйкемсез тавыш. Сөйкемсез кыланыш.* □ *Зәйнәпбану үзе болай төскә-биткә дә сөйкемсез түгел, әш дигәндә инде --- беренче кыз.* Г. Бәширов. *— Кара инде, нинди сөйкемсез гадәт, әт!* Д. Аппакова.

◇ **Сөйкемсез сөягең булу** — сөйкемсез итеп күрсәтә, күңелне биздерә торган берәр сыйфатың булу. *— Белмим инде, Сәүбән әнем, нинди сөйкемсез сөягебез бардыр.* Ф. Хөсни. *Әллә үги ананың бүтән сөйкемсез сөяге булганмы — нилектәндер аларның* [*үги кыз белән*] *борчаклары пешмәгән.* Ш. Маннур. **Сөйкемсез сөяк** — яратылмый, сөелми торган кеше. *— Ни өчен соң кешеләр шулай тупас яратылганнар? --- Килешә алмыйм мин моның белән. Минем бөтен бәхетсезлегем, сөйкемсез сөяк булуым, ихтимал, әнә шуннан килә торгандыр.* Г. Ахунов.

СӨЙКЕМСЕЗЛЕК *и.* Сөйкемсез булу сыйфаты.

СӨЙКЕМСЕЗЛӘНҮ *ф.* **1.** Сөйкемсезгә әйләнү. *— Картайган саен син әллә нишләп тупаслана һәм сөйкемсезләнә барасың.* Ш. Камал.

2. Сөйкемсез итеп күрсәтердәй берәр нәрсә эшләү, сөйкемсезлек күрсәтү; сөйкемсез булып кылану.

СӨЙКӘЛҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сөйкәү.

2. Берәр җиргә әз генә орынып яки бераз вакытка гына сөялү. || *күч. сөйл.* Берәүгә сыену, куштанлану. [*Кыз — яратмаган егетенә:*] *Моннан соң янымда сөйкәлеп йөрмәвеңне телим.* Ш. Камал. *Сөйкемсезгә сөйкәлмә.* Мәкаль.

СӨЙКӘНҮ *ф. к.* сөйкәлү (2 мәгъ.). *Сөймәгәнгә сөйкәнмибез, сөйсең ярлар табыласы.* М. Фәйзи.

СӨЙКӘҮ *ф.* Җиңелчә, әз генә орындырып сөяү. *Урчәле чана түренә капчыкны сөйкәдем дә күп итеп салынган печән өстенә менеп кырын сузылдым. Чана табаннары тын гына шыгырдап юлга борылды.* Ш. Маннур.

СӨЙЛӘМ *и.* **1.** Аралашу чарасы буларак, тел. *Язма сөйләм.*

2. Фикер белдерү өчен әйтелгән җөмлә (җөмләләр) яки тәгъбир яисә сүз (сүзләр). *Персонаж сөйләме.* □ *Аның сөйләме килешле генә булып, челтерәп ишетелә, тыңларга күңелле иде.* Г. Бәширов.

3. Телне куллануның берәр формасы яки алымы; стиль. *Шигъри сөйләм. Автор сөйләме. Гади сөйләм.* □ *Дсәр сөйләмендә тагын бер алым — укучыга мөрәҗәгать итеп сөйләү* [*бар*]. Г. Нигъмәти.

СӨЙЛӘМЧӘК *с.* Күп сөйләргә-сөйләшергә яратучы, күп сөйләүче; сүзчән. *Аның хатыны бик сөйләмчәк кеше икән.* Г. Әпсәләмов. *Сөйләмчәк фотограф авызына су капкандай булды.* Ш. Рәкыйпов.

СӨЙЛӘМЧӘКЛӘНҮ *ф.* Сөйләмчәккә әйләнү.

СӨЙЛӘМӘ *с. кит.* Турыдан-туры авазлардан файдаланып төзелә, телдән әйтелә торган (тел-сөйләм турында); *киресе:* язма. *Сөйләмә тел. Сөйләмә хикәя.*

СӨЙЛӘНЧЕК *с. сөйл.* Эшкә ашмастай сүзләр сөйләргә яратучы яки сөйләнеп кенә, әйткәнен эшләми калучы.

СӨЙЛӘНҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сөйләү. *Мин кеше турысында башкалар тарафыннан сөйләнгән сүзләргә бик сайлап кына ышанам.* Ф. Әмирхан. *Бәет турында бик күп сөйләнә бездә.* Ф. Хөсни.

2. Атап берәүгә дә мөрәҗәгать итмичә, үз алдына сөйләү. *Авыз эченнән сөйләнү. Ялгыз сөйләнү. Йоклаганда саташып сөйләнү.* □ *Үз алдына сөйләнеп, Илдус* [*сәхнәгә*] *керә.* Д. Аппакова. *— Цехтан кайтам ялгыз сөйләнеп.* Ш. Маннур. || Эшкә ашмастай, нәтиҗәсез сүзләр сөйләү. *Сөйләнеп кенә йөрмәгән, эшли дә белгән пионерларны колхозчылар ихтирам белән каршы алдылар.* Г. Гобәй. *Өйләнү — түгел сөйләнү.* Г. Тукай.

СӨЙЛӘТҮ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* сөйләү. *— Мин сөйләп бирә алмаганнарын Хафиз белән Хафизадан сөйләтерсез.* Г. Камал. *Ул вакыйганы Кадыйрдан баштанаяк сөйләтеп чыкты.* А. Алиш. || Сөйләргә мөмкинлек бирү. *Аның һәр сүзе саен әлеге хәтфә урындыктагылар кычкыра тордылар: — Сөйләтмәгез шуны!* К. Нәҗми.

2. Радио, магнитофон кебек сөйләү аппаратларын: эшләтү, тоташтыру. *Радионы сөйләтү. Магнитофонны сөйләтеп карау.*

СӨЙЛӘШ *и.* **1.** „Сөйләшү“ фигыленнән ясалган исем. *Без капчыкта ята алмады. Бу сөйләшләр --- Миңленисаның колагына чалынды. Ул, бик тырышса да, түзә алмады, теле кычытып --- Миңлезифага гына сөйләде.* Г. Ибраһимов.

2. *лингв.* Диалектның бер урынчылыкка хас төре, формасы. *Урта диалектның Минзәлә сөйләше. Көнбатыш диалект сөйләшләре.*

СӨЙЛӘШЕҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сөйләшү.

2. Сөйләшеп, сүз куешу, килешү.— *Шул арада мин, алдан сөйләшенү буенча, тәрәзәсенең түбәнге өлгесенә, рамга, үземнең ак саплы пәкемне китереп кададым.* Ф. Хөсни.— *Барысы да сөйләшенгән, диде Ксения.* К. Нәҗми.

СӨЙЛӘШТЕРҮ *ф.* 1. *Йөкл. юн. к.* сөйләшү (1, 2 мәгъ.). || Сөйләшергә мөмкинлек бирү. [*Телефонга*] *кешеләр кереп, я Казан белән, я Самара белән, я Сембер белән сөйләштерүне таләп итәләр.* И. Гази. || Сүзгә-әңгәмәгә тарту, сөйләтү. *Карчыклар аны* [*баланы*] *чакырып сөяләр, сөйләштерәләр.* Ф. Әмирхан. — *Ике көн булды* [*егетнең*] *килгәненә,* [*кызны*] *бер генә минут та сөйләштереп тора алганы күренми бит.* М. Фәйзи.

2. *Каб. дәр. к.* сөйләү (1 мәгъ.).

СӨЙЛӘШҮ *ф.* 1. Телдән файдалану; фикереңне тел белән әйтеп бирә алу. *Баланың сөйләшә башлавы. Кычкырып сөйләшү.* □ *Сафа бик аз сүзле иде. --- Өйдә дә, читтә дә ул бик аз сөйләшә. Күп вакыт ул я елмаеп, я каш җыерып кына үзенең теге я бу мәсьәләгә булган карашын белдерә.* А. Шамов. *Бичараның үләр вакытына кадәре исе дөрес булып, үләр алдыннан да сөйләшеп, үзенең васыятен әйтеп --- вафат булды.* М. Гафури. || Берәр бүтән телне: белү. *Инглизчә яхшы сөйләшү.* □ *— Мин аларча сөйләшә дә белмим. Булмый, булмый.* А. Әхмәт. *Ул ишәк кешечә сөйләшә, имеш.* Г. Тукай.

2. Берәү белән сүз, әңгәмә алып бару. *Чәй янында ул Габдулланы сансынып, олы кешеләр белән сөйләшкән кебек сөйләште.* Ә. Фәйзи. *Хатлар белән сөйләшмәсәк, Мин сине каян күрәм?* Т. Гыйззәт. || Фикер алышу. *Беренче пленумда совет язучылары социализм чоры әдәбиятының төп бурычлары турында сөйләштеләр.* М. Җәлил.

3. Сүз куешу, килешү.— *Без, интәшләр белән сөйләшеп, туйны иртәгә үк ясарга карар бирдек.* Ф. Бурнаш. *Аның бөтен йортын төзәттерергә --- уйлаганлыгы, шуның өчен әллә кайдан тимерләр, бүрәнәләр, осталар, буяучылар сөйләшеп йөргәнлеге ишетелде.* Г. Ибраһимов.

СӨЙЛӘҮ *ф.* 1. Телдән файдалану; фикереңне тел белән әйтеп бирә алу. [*Габдулла:*] *Ул бик кызык сөйли инде. Сүз саен гел „гуй, гуй!" дип куя.* [*Анасы:*] *Кыргызча сөйли ул. Тора-бара үзең дә аңлый башларсың әле. Монда аларның телен татарлар гына түгел, урыслар да аңлый.* Ә. Фәйзи. [*Төхфәтнең*] *тереләсенә дә күңел ышанмый башлады. --- Төннәрен гел саташып сөйли, эсселеге һич тә кимеми.* Ш. Камал. || Берәр турыда сүз алып бару, хәбәр итү, әйтеп бирү. *Яңа хәбәр сөйләү. Кызык сөйләү. Йомышны сөйләү.* □ *Һәркем сөйли дә сөйли, күрергә иде шуны бер мәртәбә.* Ф. Әмирхан. *Дәүли бабай үзенең яшьлеген сөйләде.* А. Әхмәт. || Җыелышта һ. б. ш. урында: чыгыш ясау. *Доклад сөйләү. Вәгазь сөйләү. Речь сөйләү.* □ *Менә, интәшләр, комсомоллар, шулай кирәк тә болай кирәк,— дип киттем сөйләп, киттем сөйләп, үземнең каушамавыма үзем аптырап калдым. Миннән соң башкалар да торып сөйләделәр.* Ә. Айдар. || Яттан уку. *Декламация сөйләү. Шигырь сөйләү.* || Берәр башка телне: белү. *Русча сөйли белү. Инглизчә яхшы сөйләү.*

2. *күч.* Чагылдыру, аңлату, белдерү, күрсәтү.— *Беләсезме, бу көй әнә шул таулар гүзәллеген сөйли.* А. Әхмәт.

СӨЙРӘЛЧЕК *с.* 1. Иң артка калып, бик әкрен йөрүче. *Һич тә ошамый Ильяска бу яңа рейс. Элегрәк, шул дыңгырдык тагылмасыз гына йөргәндә, аларны --- һич нинди җиңел машина да узып киткәне булмый торган иде. Ә хәзер иң сөйрәлчек машинаның да тынчу тузанын иснәп йөр инде.* Р. Төхфәтуллин.

2. *гади с.* Ирләр яки хатын-кыз артыннан йөрергә, сөйрәлергә (4 мәгъ) яратучы. [*Мидхәт:*] *Син уйлыйсың, мин ул сөйрәлчекне ычкындырачакмын? Җир тишегенә кереп качсын,— табачакмын.* Ф. Хөсни.

СӨЙРӘЛҮ *ф.* 1. *Төш. юн. к.* сөйрәү (1, 2, 4 мәгъ.). || Өстерәлү. *Аның артыннан, елан кебек боргаланып, озын чыбыркысы сөйрәлә.* Г. Әпсәләмов. *Сөйрәлеп бара торган зур койрык бар* [*салда*]. Г. Ибраһимов.

2. *күч. сөйл.* Бик әкрен, авырлык белән генә хәрәкәт итү.— *Син идеңме, беркөн Урам буе исереп сөйрәлдең?* М. Җәлил. *Өстән туплар очкан чак иде, Үлем баржалары сөйрәлгәндә Дүрт иделнең өстекан иде.* Ф. Кәрим. || Ирексезләгәнгә-көчләгәнгә генә һәм карыша-карыша, артка тартыла-тартыла гына бару. *Хәсәнша Шәфине җитәкләгән, Шәфи — бозауны. Бозау сөйрәлеп, тартылып килә.* М. Фәйзи.

3. *күч. сөйл.* Эштә, хәрәкәттә, үсештә: бүтәннәрдән артка калып бару, артта булу.— *Кимсенәсеңме, артта сөйрәләсең килмиме?* Г. Бәширов.

4. *күч. гади с.* Әдәп-мораль таләпләре белән исәпләшмәстән, хатын-кыз артыннан яки ирләр-егетләр артыннан йөрү.— *Бер генә дә оятың юк икән! Ир хакы димәдең, халыктан ояльмадың, бер нәфесеңне тыя алмыйча сөйрәлеп йөрдең! Нинди тәүфыйклы иреңне мыскыл иттең!* Г. Бәширов.

СӨЙРӘЛҮЧЕ *с. зоол.* Гадәттә гәүдәсен җирдән шудырып-сөйрәп яки үрмәләп хәрәкәт итә торган умырткалы хайваннар (елан, кәлтә, крокодил, ташбака һ. б.) классыннан булган. *Сөйрәлүче хайван.*

СӨЙРӘТКЕЧ *и. диал.* Салам, печән кебек нәрсәне (йөккә салмыйча гына) кибәнгә-эскерткә җыйганда тарттыру җайланмасы. *Сөйрәткечләргә печән өя башладык. Нәнирәкләр, тезген тотып, печәнне болын уртасынарак, бер биек кибән куелачак урынгарак тарттыра.* Г. Хәсәнов.

СӨЙРӘТҮ *ф. Йөкл .юн. к.* сөйрәү. [*Бай — хезмәтчеләре турында:*] *Әгәр берсе каршы килеп җавап бирсә, Урамга сөйрәтәм дә тиз ташлатам.* М. Гафури. || Тарту көче ярдәмендә сөйрәү, өстерәтү-тарттыру. *Трактор белән бүрәнә сөйрәтү. Ат койрыгына тагып сөйрәтү.* □ *Ул саламны егетләр, бөтен чүмәләсе белән бер юлы әлдереп алып, ындыр читендәге салам эскертенә таба сөйрәттеләр.* Г. Бәширов. || *диал. к.* сөйрәү (1, 2 мәгъ.). *Ул ике монахның иңбашларына таянган килеш аякларын көчкә сөйрәтеп ишектән кергән озын кара киемле архиерейны күрде.* К. Нәҗми. *Әхмәт зур киез каталар сөйрәтеп бәләкәй этләр белән куыша-куыша шаярып кайнашкан Гарәпшаға күз төшерде.* Ш. Камал.

СӨЙРӘҮ *ф.* 1. Җирдән, идәннән яки судан күтәрмичә тартып бару; өстерәү. *Көймәне судан читкәрәк сөйрәү.* □ *Аучы белән Актырнак бүрене сөйрәп ишек алды уртасына керәләр.* А. Алиш. *Сигез яшьтә идем, чыбыркыны Иңгә асып сөйрәп йөргәндә.* Ә. Еникәй. *Гәүдәсеннән ун кат зур йөкне дә Сөйри кабып эшчән кырмыска.* Ш. Мөдәррис. || *күч.* Ирексезләп яки көчләп алып бару. *Габиш аның* [*бәрәннең*] *ботларыннан тотты да акыртып сөйрәп чыгарды.* Ф. Кәрим. *Кызларның берсе аны кулыннан тотып уенга сөйрәмәкче булды.* Г. Әпсәләмов.

2. Күтәрмичә, шудырыбрак, гадәттә тезне дә бөкмичә атлау (аякны). [*Яралы интәше*], *Шәмсинең иңбашына таяна төшеп, аякларын көч-хәл белән генә сөйри.* Г. Бәширов. *Ул йөргән чагында сул аягын бераз сөйрәп ала иде.* Ш. Камал.

3. *күч. сөйл.* Алып бару, башкару (авыр эшне-тормышны). *Читенлекләр белән каршы килсәң, Син безгә кил, бергә сөйрәрбез.* Ш. Маннур. *Нинди эш кушсаң да, сөйри ул.* Сөйләмнән.

4. *күч. сөйл.* Кадерсезләп яки яратмыйча киеп яисә күтәреп йөрү, йөртү. *Бала-чаганың олылар киемен сөйрәп чана шуарга чыгуы.* □ *Көн дә яңгыр, көн дә кожан сөйрә, дллә ничек --- тышта күңелсез.* Ш. Мөдәррис.

СӨКӘ *и.* Эчкә таба очлаеп кереп тора торган тар авызлы итеп озын чыбыктан үргән, елгада һәм күлдә эрерәк балыкларны аулау коралы, тозагы. *Балыгын алу өчен янына капкачлы кечкенә тишек ясап үрелгән сөкә. Балыкның сөкә эченә җимгә алданып керүе. Сөкәне балыклырак җиргә салу.* □ *Безнең Укмас суын беләсез — балыкка дип куйган сөкәләр була анда.* Ф. Хөсни. *Бабай сөкә бавын чишеп кәрәкәләрне суга җибәрде.* Р. Батуллин.

СӨКӘЛЕК *с.* Сөкә үрү өчен дигән яки шуңа яраплык яисә җитәрлек. *Сөкәлек чыбык кисеп алып кайту.*

СӨЛГЕ *и.* Сөртенү өчен махсус сугылган яки кисеп тегелгән озынча тукыма кисәгеннән гыйбарәт әйбер. *Кижеле сөлге. Чүпләмле сөлге. Сөлге чигү.* □ *Сабан туенда батыр калып, бер кочак чиккән сөлге күтәреп кайтучы егет бит ул.* И. Гази. *Госман сөлгене суга манчып алды да аның [авыруның] маңгаена куйды.* А. Шамов.

СӨЛГЕЛЕК *с.* **1.** Сөлге сугу яки кисеп тегү өчен дигән я шуңа яраплык яисә җитәрлек булган. *Сөлгелек киндер.*

2. *и. мәгъ.* Сөлгегә дигән яки шуңа яраплык яисә җитәрлек материал. *Сөлгелек сугу. Кибеттән сөлгелек сатып алу.*

СӨЛЕК *и.* Хайваннар тәненә ябышып, аларның канын суырып яши торган төче су суалчаны. *Күлдә су коенганда балтырга сөлек кадалу. Дәвалау максаты белән тәнгә сөлек салу.*

◇ **Сөлек кебек** — 1) зифа, төз буйлы. *Сөлек кебек зифа булып буйга үсеп киткән кыз бала бик яшь иде әле.* М. Әмир. *[Шәрәф] сөлек кебек булып үсеп, кызлар сокланырлык егет булып бара.* М. Фәйзи. || Зифа гәүдәле (ат һ. б. ш. хайван турында). *Киртә буендарак атлар йөреп тора. --- Барының да эчләре суырылган. Бары да карап торырга сөлек кебек маллар. Болар чабышкылар.* Г. Ибраһимов; 2) паразит, ерткыч кебек. *Безнең канны сөлек кебек суручы байлар, бүре кебек ерткыч министрлар булмаса, сез дә, мин дә бу хәлгә калмас идек дип әйтте ди [егет].* А. Алиш.

СӨЛЕКЧЕ *и.* Сөлек салучы, шул эш белән шөгыльләнүче. *Нурбиби сызлана: — дй ходаем!.. Шәһит, әллә, мин әйтәм, сөлекче Сәрби әбине чакыртыйкмы?* Г. Минский.

СӨЛӘЙМАН: сөләйман балыгы *зоол.* — сельдьсыманнар отрядыннан, төче суда яши торган яки күчмә (кызгылт яисә алсу итле һәм кыйммәтле) балык; *русчасы:* лосось.

СӨМБЕЛ *и. бот.* Хуш исле һәм кыңгырау сыманрак вак-вак чәчәкле, суганчалы күпьеллык үсемлек; шуның оешма чәчәге; *русчасы:* гиацинт.

СӨМСЕЗ *с.* **1.** Тоючанлыгын бик киметкән яки югалткан; хәлсезләнгән. *Мусаның сөмсез аяклары җирдән бөтенләй сөйрәлеп бара иде инде.* Ш. Маннур.

2. Тупас, дорфа, әдәпсез. *Аягына басып йөри башлау белән үк Габдулланың бөтен тормышы үзенә тапшырылды. Ул биргәндә ашады, бирмәгәндә үзе үрелеп алды.— Сөмсез! — дип, кашык белән аның кулына суктылар, өстәл яныннан кудылар.* Ә. Фәйзи.

СӨМСЕЗЛЕК *и.* **1.** Тоймау сыйфаты яки халәте; хәлсезләнгәнлек. *Малайның бу көтелмәгән хәбәрдән тирә-ягы чайкалып китте, тез буыннарында нинди дер сөмсезлек тоеп, урындыкка лып итеп утырырга мәҗбүр булды.* Ш. Маннур.

2. Тупаслык-дорфалык, әдәпсезлек. *Ялкаулык белән сөмсезлек барыннан да көчлерәк.* З. Бәшири. *Хайваннар [дуңгызның] бу сөмсезлегенә бик каты ачуланганнар.* Н. Исәнбәт.

СӨМСЕЗЛӘНҮ *ф.* **1.** Тоючанлыкны бик киметү яки югалту; хәлсезләнү. *Баштарак Арслан аны култыклап барды. Ләкин Муса аякларының сөмсезләнүе тагын да көчәю сәбәпле, олы гәүдәле Арсланның да аны әйдәргә көче җитмәс булды.* Ш. Маннур.

2. Тупаслану-дорфалану.

СӨМСЕР: сөмсер коелу — бик борчылып, кәефсезләнеп, йөз каранғылану. *Бүген ул [һәдия карчык] ничектер ачыграк чырайлы. Кичәгедәй сөмсерләре коелып, зәһәр чәчеп йөрми.* К. Нәҗми. *Сөмсерләрең бик коелган, дллә юкмы саулыгың?* Җыр.

СӨННӘТ I *и. дини.* Ирлек эгъзасының очын каплап торган тирене кисеп алу йоласы. *Сөннәтне таныма.* □ *Дин китаплары сөннәт йоласының башланып китүен шул рәвешчә итеп, аны мөселманлык мәһере итеп бәян кылалар. Асылда исә сөннәт мөселманлык мәһере булудан ерак тора.* Г. Гобәй.

◇ **Сөннәте булмау** — сөннәткә утыртылмаган булу. **Сөннәткә утырту (бирү)** — малайларның: җенес эгъзасын Мөхәммәт йоласынча очыннан кисү.

СӨННӘТ II *и. дини* **1.** Мөхәммәт пәйгамбәрнең вәгазьләре-күрсәтмәләре, эш-гамәле, йоласы. *Пәйгамбәрнең сөннәте өч.* Ироник-шаяртулы мәкаль. *[Хажи:] Шәригать боерыгы буенча гамәл итәргә кирәк. --- [Мөхәммәтнең] сөннәтен җиренә җиткермичә һич ярамый.* Ш. Камал.

2. *с. мәгъ.* Шәригатьтә мәҗбүри булмаган, Мөхәммәт күрсәтмәләре нигезендә генә үтәлә торган (йола һ. б. турында).— *Туктале, сәлам бирим әле әүвәл мин сиңа, дустым Сөләйман, әссәламегаләйкем! Сәлам бирү — сөннәт, алу — фарыз, син аны ал!* С. Рәмиев.— *Тозны аштан элек кабаргамы, соң кабаргамы? Дллә элек тә, соң да кабу сөннәтме?* М. Галәү.

СӨННӘТЛЕ *с. дини.* **1.** Сөннәткә утыртылган. — *Кандала базына ябарга кирәк бу сөннәтле жандармны!* К. Нәҗми.

2. *иск.* Гадәттә чалма астыннан кия торган, камалы (бүрек турында). *Сәхәби сөннәтле бүреген салып чөйгә элеп куйды һәм --- фәс алып киде.* Ә. Фәйзи.

СӨННӘТЛӘҮ *ф. дини.* Сөннәткә утырту, сөннәтлә итү. *Туганмын. Сөннәтләргә кирәк булгач кычкыртмырып сөннәтләгәннәр дә, шуның белән мөселманлык паспортын биреп, күлмәк койрыгымны төенләп, якты кояш астына җибәргәннәр.* Һ. Такташ.

СӨННӘТСЕЗ *с. дини.* Сөннәтле (1 мәгъ.) түгел, сөннәткә утыртылмаган. *Сөннәтсез малай.*

СӨННӘТЧЕ *и. дини.* Сөннәткә утыртучы. *Балалар кырып йөрүче сөннәтче карт турында авыл советы кешеләренә белдерү өчен дип, ул ашыгып-ашыгып авыл советына таба атлады.* Ф. Хөсни.

СӨРГЕН *и.* **1.** Читкә сөреп, гадәттә бик еракка җибәреп яшәтү җәзасы. *Сөрген еллары. Сөрген срогын тутырып кайту.* □ *Укытучы Гафур Казанның атаклы бер врачы дачасында сөргеннән соң дәваланып ята иде.* К. Нәҗми. *Патша хөкүмәте Сахалинны файдасыз утрау, фәкать сөрген өчен генә яраклы урын дип исәпләгән.* Ә. Маликов.

2. Җәза тәртибендә сөреп җибәреп яшәтү урыны. *Революционерларның сөргеннән качуы. Сөргеннән кайту.* □ *Ул чакта сөргендә иде әле ипташ Ленин.* Г. Гобәй. *Патша сөргенендә гомерен кыскартып яткан --- бу егетнең күңелен ачу катыш ирония билгән.* М. Мәһдиев.

СӨРГЕЧ *и.* Төрле машинада: кар һ. б. ш. җиңел катламны сөрү, буразналау җайланмасы. *Тракторлар,*

бурадай кар сөргечләрен тагып, ташу сулары буарга чыкканнар. Р. Төхфәтуллин.

СӨРДЕРҮ *ф.* **1.** *Йөкл. юн. к.* сөрү I.— *Атны аны ялыннан өстерәп сабан сөрдереп булмый.* Р. Ишморат.

2. Авыл хуҗалыгы машиналары белән сөрү. *Бәрәңге бакчасын кечкенә трактор белән сөрдерү. Парны алты төрәнле сабан белән сөрдерү.*

СӨРЕМ *и.* **1.** Корымлы куе төтен. *Лампа сөреме.* □ *Яшәгән урыныбыз — иске баракның кысан бер бүлмәсе. Бердәнбер тәрәзә. Аның пыяласы парланса, паровоз сөреме катнаш су ага иде.* Б. Камалов.

2. *күч.* Зур кайгы, афәт һ. б. ш. *Хәсрәт сөреме.* □ [*Кырык беренче елда*] *дөньяны сугыш сөреме каплады. Бөтен халыкта сугыш кайгысы, сугыш!* Г. Бәширов. *Кунмасын дип коллык сөреме, Аямадык канны, гомерне.* Ф. Кәрим. || *кит.* Зарарлы карашлар, реакцион фикерләр һ. б. ш. турында. *Башыннан искелек сөреме чыгып бетмәгән кешеләр. Дин сөреме.* □ [*1905 нче елдан соңгы чорда*] *халык аңыннан революция фикерләрен --- чыгарып, аны динчелек, аллага буйсыну, капитализмга баш ору, милләтчелек сөремнәре белән томаларга тырыштылар.* М. Җәлил.

СӨРЕМЛЕ *с.* **1.** Сөрем чыгарып яна торган (ут һ. б. турында). *Лампаның ялкыны бик сөремле булу. Сөремле газ.*

2. Бик сөремләнгән (һава һ. б. турында). *Сөремле куыкны чистарту. Сөремле бүлмә.*

СӨРЕМЛӘНҮ *ф.* **1.** Янганда сөрем чыгару; сөремләү. *Аз гына сөремләнеп янып торган җиделе лампа аның кул хәрәкәтләрен күзәткән сыман әле уңга, әле сулга каерыла.* А. Гыйләҗев. *Кайәр төшкән нәрсә* [*лампа*], *нигәдер сөремләнмәкче була, аратирә, сүнәргә теләгәндәй, өзек-өзек талпынып куя.* А. Шамов.

2. Өстенә сөрем куну (куык, тәрәзә һ. б. турында). *Куык сөремләнү.* □ [*Солдатның*] *битләре дары төтененә сөремләнеп беткән; ярсудан, дулкынланудан ул бераз иләс-миләсләнгән.* И. Гази. || Сөрем тулу (бүлмә турында). || Сөрем белән катнашу (һава турында).

СӨРЕМЛӘҮ *ф.* **1.** Янганда сөрем чыгару. *Сөремли торган лампа.*

2. Сөрем чыгарып, һаваны, бүлмәне һәм төрле әйберләрне, өслекләрне сөремле итү. *Машина газларының урам һавасын сөремләп агулавы.*

СӨРЕНТЕ *с. диал.* Сөрелә торган (җир турында).

СӨРЕШ 1. Сөрү I (1 мәгъ.) фигыленнән ясалган исем.

2. сөреше. Сөйләмнең, контекстның мәгънәсе, эчтәлеге турында. *Мәгънәне сүз сөрешеннән аңлау.* □ *Татарчадан сүзләр табылмаган урында мәгънәнең теләве, ана теленең сөреше буенча --- татар тамырларыннан яңа сүзләр төзелер.* Г. Ибраһимов.

СӨРЛЕГҮ *ф.* **1.** Үсеп утырган үлән, куак һ. б. турында: бер якка авышу яки аву, яту. *Игеннәрнең көчле яңгырдан сөрлегеп калуы.* □ *Уңда арыш чүмәләләре күренде, сулда җил уңаена сөрлеккән тары, саргаеп, куырылып беткән ясмык кырлары җәелеп китте.* И. Гази. [*Йомшак бодайның*] *саламы сына, тиз сөрлегә. Аз гына җилгә дә каршы тора алмый.* С. Рафиков.

2. Ишле төркемнең кинәт кузгалып бер якка авышуы яки юнәлүе турында. *Йөгерүчеләрне күрергә дип халык алга сөрлекте. Кеше дулкыны Нурулланы да эләктереп алып китте.* И. Гази. *Абзардагы сарыклар куркышып бер читкә сөрлектеләр.* Ф. Хөсни. *Автобус алга омтыла. Без кешеләр белән артка сөрлегәбез.* Р. Батуллин.

3. Абыну. *Ул казылып эштән чыккан чокыр-чакырлы мостовой уртасыннан ташларга сөрлегә-сөрлегә шәһәрнең татарлар тора торган ягына таба китте.* К. Тинчурин. *Атам биргән аргамагым Үргә каршы сөрлегә.* Җыр.

4. *күч.* Эштә-тормышта: ялгышлык эшләү, уңышсызлык-бәхетсезлеккә очрау.— *Ни сәбәпле адым саен диярлек сөрлегә һәм чигенә, хәтта җиңелә бара соң әле ул?* Э. Касыймов.

СӨРМӘ *и.* **1.** Химик элемент, көмеш сыман аксыл, уалучан металл; *русчасы:* сурьма.

2. *иск.* Чәч, каш, керфек һ. б. ш. каралта торган буяу. [*Үзе эшләп алган акчасына*] *шәл алды, күлмәк ясатты* [*кыз*], *иннек белән кершәнгә, сөрмәгә дә өлеш калды.* Г. Ибраһимов. *Тама-тама күзеннән күз яше, Уң күзеннән юылды сөрмәсе.* Н. Исәнбәт.

◇ **Сөрмә тарту** — кашны, күзне һ. б. сөрмәгә (2 мәгъ.) буяу. *Хатын-кызның сөрмә тартуы.* □ *Икенче көнне кари әфәнде, күзләренә кап-кара итеп сөрмә тартып, байлар белән күрешер өчен базарга чыкты.* Ф. Әмирхан.

СӨРМӘЛЕ *с.* Сөрмә тарткан, сөрмәгә буялган (каш, күз һ. б. турында). *Хафиз белән Хафизаның сөрмәле икән күзләре.* Г. Камал.

СӨРМӘЛӘҮ *ф.* Сөрмәгә буяу, сөрмә тарту. *Ирем икенче хатын алмасын дип, сөрмәлидер кашларын* [*Байбикә*]. Ш. Мөхәммәдев.

СӨРСҮ *ф.* **1.** Бозылып начар ис чыгара башлау. *Песинең иткә буе җитмәгәч, сөрсегән дип әйтә ди.* Мәкаль.

2. Начарлану, бозылу (һава турында). || Һавасы начарлану, бозылу (бүлмә һ. б. турында). *Революциягә чаклы бу авылда русча укый-яза белүче бер генә кеше дә булмаган. Яшьләр кыйшык түбәле сөрсегән мәдрәсәдә еллар буе әфтияк чәйнәгәннәр.* Ш. Рәкыйпов.

СӨРТЕҢҮ I *ф.* **1.** Юынгач, тирләгәч тәннең юешен сөртү. [*Марат*] *тышкы сөлге белән сөртенеп керде, шушындый чатлама суыкта кар белән ышкынган.* Т. Гыйззәт. [*Зиннәт*] *кулъяулыгын чыгарды. Ләкин сөртенмәде.* Г. Бәширов.

2. Үзеңә ислемай кебек нәрсә сибү, сөртү. [*Купшы егет*] *йөзләренә, күзләренә әллә ниләр сөртенә.* Һ. Такташ.

СӨРТЕҢҮ II *ф.* **1.** Абыну. *Урманда йөргәндә агачка сөртенеп егылу. Караңгы коридорда сөртенү.* □ *Яхшы ат та кайчак сөртенә.* М. Җәлил.

2. *күч.* Эштә-тормышта: ялгышлык эшләү; уңышсызлык-бәхетсезлеккә очрау.— *Үзем сөртендем шул, берәүгә дә үпкәләр хәлем юк.* М. Гали. *Ләкин, туташ, сөртенгән нәрсәгез — мәхәббәт ул.* М. Фәйзи.

СӨРТКЕЧ *и.* Сөртеп (1, 2 мәгъ.) чистарта торган әйбер. *Тузан сөрткеч.* □ *Ул аягын баскыч төбендәге резина сөрткечкә ышкыды.* М. Мәһдиев. *Машина юлдагы күлләвеккә кергән саен алгы тәрәзәгә су чәчри, пыяла сөрткеч арлы-бирле йөреп* [*сөртә*]. Каз. утл.

СӨРТҮ *ф.* **1.** Чүпрәк яки бүтән әйбер белән берәр нәрсә өстеннән бетерү, китәрү, алу (тузанны, юешне, пычракны һ. б. ш.). *Урындыктагы тузанны сөртү. Тирне сөртү. Киселгән җирдәге канны сөртеп алу.* □ [*Сәгыйть*] *сөтле чокырын кулы белән бер читкә этеп куйды һәм иреннәренә утырып калган сөт күбекләрен учы белән сөртеп алды.* А. Шамов.

2. Берәр нәрсәнең өстен кул яки чүпрәк һ. б. ш. белән чистартып тузаннан, юештән, пычрактан, чүптән арындыру. *Күзлекне сөртү. Аякны паласка сөртү. Тәлинкәләрне тастымал белән сөртү. Борын сөртү. Кулны сөлгегә сөртү. Битне сөртү.* □ [*Асрау кыз*] *көзге, урындык вә башка нәрсәләрне сөртә-сөртә, үз алдына сөйли.* Г. Камал. *Кая, чүпрәгеңне*

бирче, кәвеш табаннарын сөртим әле. М. Хәсәнов.

3. Сылап йоктыру, ягу. *Җәрәхәткә дару сөртү. Өшегән җиргә каз мае сөртү. Ярылган кулга вазелин сөртү. Иннек-кершән сөртү.* □ *Мәдинәнең бармагына йод сөртеп, марля белән урадылар.* Ш. Камал. || Ислемай, одеколон кебек нәрсәне: сибү. *Ул хатка ислемай сөртте дә конверт эченә салып ябыштырып куйды.* Ф. Әмирхан. *Хушбуйны өсләремә, чәчләремә сөрттем.* Ә. Айдар.

4. *күч. сөйл.* Урлау. *Майлы әйбер исең сизенгән соры мәче теләгенә иреште. Кем белә, күпмесен сөртергә батырлыгы җитәр иде икән, тик Сәгъфиянең күзе кәрзин өстенә борылды.* К. Нәҗми.— *Берәр яшь шагыйрьнекен сөртмәгән булсаң. Бик ышанып та җитмим. Син менә безнең алда чыгар* [*шигырьне*]. Г. Мөхәммәтшин.

СӨРХӘНТӘЙ *и.* Эшлексезләнеп йөрүче, ялкау. *Ак сөяк булып, сөрхәнтәй булып үсми аның оныгы, яшьтән үк эш эшләп, һөнәрле булып үсә.* Г. Ахунов. [*Вәли — капка янында торып, бозауларның кырга узганын күрми калучы малайларга:*] *Сез нәрсә? Уйнап кына йөрисезме, сөрхәнтәйләр?* С. Рафиков.

СӨРӘН *и. иск.* **1.** Авыл бәйрәмендәге атлы спорт уеннары һәм ярышлары.

2. Шундый ярышларга өндәп, чакырып, аваз салып йөрү; шул йола. *Сагынып көткән сабан туйлары җитте.* --- *Малайлар, яшүсмерләр, иртә таңнан торып, язгы кояш белән бергә үк диярлек сөрән чабарга чыгып, сабан туен башлап җибәрделәр. Күңел түзмәде, Мактый бабайның --- алашасына атланып мин дә сөрәнгә чыктым. Бөтен урамнарны тутырып иңләп, кибеп җитмәгән пычракларны чатыр-чотыр чәчрәтеп, шаулап, шәрып, көлешеп:— Сөрәнгә, сөрәнгә, сөрәнгә! Сөрән беткәч, сабан-сука төрәнгә!— дип такмаклый-такмаклый чабып йөрибез.* Ш. Маннур.

◇ **Сөрән кычкыру** — *к.* сөрән салу. *Агайларның кайберәүләре сөрәннәр кычкырып аю качырырга тотындылар, кайберәүләре утлы агачларны алып, чаткыларын чәчеп селкә башладылар.* М. Гафури. **Сөрән салу** — 1) сөрәнгә чакырып, өндәп аваз салу, кычкыру; 2) гомумән, өндәп, чакырып аваз салу, кычкыру. *Күбеккә баткан җирән атларын чыбыркылап, кыргый тавыш белән сөрән салып басу капкасыннан кораллы отряд килеп керде.* К. Нәҗми. *Атланыгыз атларыгызга, алыгыз сөңгеләрегезне, тагыгыз чукмарларыгызны! дип сөрән салыр идем.* М. Әмир; 3) каты кычкыру; каравыл салу. *Хулиган!— дип сөрән салды Илгиз.* Б. Камалов. *Таң әтәче һәр төнне һаман шулай сөрән салып кычкыра да иртә белән үзе юкка чыга иде.* М. Шабай. **Сөрән сугу** — эшлексезләнеп тырай тибеп йөрү. *Данилов кинәт кенә борылды да ачуланып кычкырды: „Ни эшләп йөрисез монда сөрән сугып? Марш роталарыгызга!"* Г. Бәширов.

СӨРӘНЛӘҮ *ф. сир.* Өндәп, чакырып аваз салу, кычкыру. || Гомумән, көчле аваз салу, кычкыру. *Юл тар, борылмалы, ике як — кара урман. Ялгыз бару бик куркыныч. Аюның нәкъ өстенә барып чыкмас өчен, һәрвакыт кычкырып, сөрәнләп барырга кушканнар иде. Мин аларның сүзләре буенча минут саен кычкырып барам.* М. Гафури.

СӨРӘНЧЕ *и. иск.* **1.** Сөрәндә, ярышта катнашучы.

2. Сөрәнгә өндәп, сөрән салып йөрүче. *Урам башыннан атка атланган сөрәнчеләр килеп чыкты... Алгы атка атланган сөрәнченең кулында шактый озын колга, аның башында яшелле-күкле яулык бәйләнгән һәм ул җилгә очынып, җилфердәп тора иде.* --- *Сөрәнче капка саен туктап:— Апалар, сеңелләр, чыгарасы бүләкләрегезне чыгарыгыз, көттермәгез, хәзер мәйданны башлыйбыз!— дип кычкырды. Килен төшергән йортлар алдында сөрәнчеләр озаграк тукталдылар.* Ә. Фәйзи.

СӨРҮ I *ф.* **1.** Сукалау. *Җир сөрү. Туңга сөрү. Трактор белән сөрү. Тирән сөрү.* □ *Агач сабан, рәте юк, юньле сөрми, Кай җирләрне чи калдырып китә ташлап.* М. Гафури.

2. *күч.* Аяк астындагы пычракны, карны һ. б. ш.: ерып бару. *Миңнулла, Гафият һәм тагын берничә кеше атларын урман буенда калдырдылар да, тездән җепшек кар сөреп, нарат агачлары арасына кереп киттеләр.* И. Гази. *Әле дә исемдә, яңа гына каты сугыш булып үткән, хәрабә хәленә килгән урам буйлап пычрак сөрә-сөрә барам.* А. Шамов. || Дуңгыз һ. б. ш. хайванның җир өстен актарып-ермачлап бетерүе турында.— *Менә бәрәңге бакчасын сөрү кебек әшәке гадәте булуы яман мәлгуньнең* [*дуңгызның*]. М. Әмир.

СӨРҮ II *ф.* **1.** Ачуланып, кыйнап һ. б. ш. рәвешчә куу, бөтенләйгә куып җибәрү. *Дошманны илдән сөреп чыгару.* □ *Юк гаеп өчен байлар приказчикны урыныннан сөрмәсә иде.* Ш. Мөхәммәдев. *Мин тезләндем синең алларыңа, Мине сөрмә, сеңлем, каршыңнан!* Н. Исәнбәт.

2. Сөргенгә җибәрү. *Патша хөкүмәтенең революционерларны төньякка яки Көнчыгышка сөреп җәза бирүе.* □ *Кичә Булатны Себергә сөрделәр.* Г. Ибраһимов.

СӨРҮ III *ф. Берничә төрдәге сүз белән генә кулланыла.* Гомер, тормыш һ. б. ш.: алып бару, кичерү, үткәрү, яшәү. *Аталары, әкрен гомер сөреп, Картаешып үлеп киттеләр.* Ш. Маннур. *Золмәт һаман көн сөрәлмәс!* С. Рәмиев. *Барча милләтләр тигез тормыш Сөрә, һәрберсе шат.* М. Гафури. || Кәеф-сафа, рәхәт һ. б.: кору, тату, күрү. *Күрдем әле синең залимеңне: һаман кәеф сөрә, типтерә.* Г. Тукай. *Байлар бик күп йөрделәр, Төрле рәхәт сөрделәр.* Г. Камал. *Эшче халык яшәсен, Сөрсен дөнья сафасын.* Ш. Бабич. || Хөкемне һ. б. ш.: гамәлгә ашыру, йөртү. *Солтанлык сөрү. Патшалык сөрү.* □ *Хөкем сөрер изге дуслык бөтен җирдә.* Ә. Исхак. *Бер вәзир, ни сәбәп иләдер, --- кортлар, еланнар патшалык сөрә торган мәмләкәткә китте, дөресен генә әйтсәм, вафат булды.* Г. Тукай.— *Әле монда һаман Садыйк бай хуҗалык сөрәмени?* Ш. Камал.

СӨРҮЛЕ *с.* Сөрелгән, сукаланган. *Сөрүле басу.*

СӨРҮЛЕК *с.* Сөрүгә I (1 мәгъ.) яраклы; сөрелә торган. *Сөрүлек җирләрнең мәйданын арттыру.* || *и. мәгъ.* Сөрүгә яраклы яки сөрелә торган җир. *Республика буенча сөрүлекләр бер колхозга уртача дүрт мең ярым гектар чамасы туры килә.* Каз. утл.

СӨТ *и.* **1.** Хатын-кызларда һәм имезүче ана хайваннарда: махсус бизләрдән бүленеп чыга (һәм яшь баланы туйдыра) торган туклыклы ак куе сыекча. *Сөт бизе.* □ *Энекәем бәхил булсын имезгән сөтләренә.* Җыр. *Бия, бер-ике тарткач та, рәхәтләнеп, аякларын ике якка аерды, имчәкләрдән сөт агып китте.* Г. Ибраһимов. || Кайбер хайваннардан (күбесенчә сыердан) савып алып, азык итеп кулланыла торган сыекча. *Сөт аерту. Кайнаган сөт, Ачыган сөт. Сөт фермасы. Яңа сауган сөт. Сөт чүлмәге. Куе сөт.* □ *Хәлим бер телем икмәк белән бер чокыр кәҗә сөтен ашады да ялт итеп чыгып та китте.* И. Гази.— *Сыерыбыз чирләде, җәй буе сөт бирмәде.* К. Тинчурин. *Аннан, зур чүен белән, сөттә пешкән хуш исле кайнар бәрәңге килеп чыкты.* Г. Бәширов.

2. Кайбер үсемлекнең так яки таксыл сүле. *Билчән сөте. Кокос сөте.* □ *Үзләрен хәзер куып чыгарачакларын белгән шикелле, алар* [*солы басуына*

кергән атлар] *яңа гына сөт кергән сусыл солыны ашыгып йолкый да башлаганнар.* Ш. Мөдәррис.

3. Кайбер матдәләрнең ак яки аксыл эремәсе. *Цемент сөте.* □ — *Завод бик иске шул, купец Любимовлар заманында ук салынган. Известь сөте куып торучы поршеньлы насослар тузып беткән.* Г. Ахунов.

◇ **Сөт тә юк, йон да юк** — бер файда да юк. *Мәеткә сезнең ул* [*дога*] *укуыгыздан сөт тә юк, йон да юк.* Г. Гобәй. **Сөт өсте** — сауганнан соң бераз торгач сөтнең өстендә барлыкка килә торган куе, майлы катлавы.— *Менә, балам, бик әйбәтләп сөт өсте кушып катык әзерләдем үзеңә.* Р. Ишморат. **Сөте кипмәгән (кибеп җитмәгән)** — *к.* авызыннан сөте кипмәгән. [*Гарәп:*] *Сөте кибәлмәгән Таһирләргә Җир йөзләре җәннәт бүгенгә.* Ф. Бурнаш. **Сөттән ак, судан пакь** — әз генә дә гаебе, гөнаһы юк. *Беребез дә сөттән ак, судан пакь түгелбез бит... Сөйләшеп торган өчен шулай кешеләрне хур итәргә кирәк микәнни?* М. Гафури.

СӨТЛЕ *с.* 1. Эчендә сөте булган, сөт салынган (савыт-саба турында). *Сәгыйть ашавыннан бөтенләй туктады, сөтле чокырын кулы белән бер читкә этеп куйды.* А. Шамов. [*Яңгыр буткасы пешертергә йөрүче*] *малайлар, сөтле чиләкләрен, майлы табакларын, ярмалы капчыкларын күтәреп, читәннәрне, коймаларны таяк белән кыйный-кыйный урам буйлап киттеләр.* И. Гази.

2. Сөтне чагыштырмача күп бирә, саудыра торган (хайваннар турында). *Сөтле кәҗә.* □ — *Бик сөтле сыерга туры килдем бит әле мин.* --- *Бер дә харап. Иртә-кичле бераз чиләк сөт бирә дә тора.* Р. Ишморат.

3. Организм күзәнәкләрендә сөт рәвешендәге сүле булган (үсемлекләр турында). *Сөтле үлән.*

4. Сөт катыштырылган, кушылган (аш, чәй һ. б. ш. турында). *Сөтле өйрә. Сөтле чәй ярату. Сөтле тоткмач.* □ *Нурулла сөтле ашны бик ярата.* А. Гыйләҗев. *Аларның сөтле камырдан пешергән дучмаклары ашап туйгысыз.* Ш. Маннур.

СӨТЛЕГӘН *и. бот.* Агулы ак сөтле үлән; *русчасы:* молочай. *Аланчыкка хәтфәдәй ямь-яшел йомшак үлән үскән. Д үләндә сап-сары сөтлегәннәр, шәмәхәзәңгәр кыңгырау чәчәкләр.* А. Расих.

СӨТЛЕЛЕК *и.* Сөтле булу сыйфаты, хәле. *Сыерның сөтлелеген белү.*

СӨТЛЕЛӘНҮ *ф.* Сөтлегә (2, 3 мәгъ.) әйләнү.

СӨТЛӘП *рәв.* Сөт белән, сөт кушып (ашау-эчү турында). [*Нәгыймә*] *ирен кararга тотынды. Аның яткан җиренә таба кечкенә өстәл китерде. Сөтләп чәй ясап бирде.* Г. Ибраһимов.

СӨТЛӘЧ *с.* Сөтне күп бирә торган (хайван турында), сөтле. *Сөтләч кәҗә.*

СӨТСЕЗ *с.* Сөтне бик әз бирә яки бөтенләй бирми башлаган (гадәттә сыер, кәҗә турында).

СӨТЧЕ *и.* Сөт сатучы яки ташучы. *Сөтче хатыннар килеп тә җиткәннәр: иртәнге пароходны көтәләр.* И. Гази.

СӨТЧЕЛ *с.* 1. Сөтне чагыштырмача күп бирә торган, сөтләч. *Яхшы, сөтчел сыерлар аерым группага тупланды, киләчәктә алар нәсел үзәге булачак.* М. Маликова.

2. Күзәнәкләрендә сөт сыман сүле-суы булган (үсемлекләр турында). *Сөтчел билчән.*

СӨТЧЕЛЕК *и.* Авыл хуҗалыгының сөт җитештерү, сөт терлеге үрчетү белән шөгыльләнә торган тармагы. *Колхозның сөтчелектән табыш алуы. Сөтчелеккә игътибарны юнәлтү.*

СӨХБӘТ *и. иск. кит.* Сөйләшеп утыру; әңгәмә. *Сөхбәтләр тәэсир итә дигән сүз бар. Һәрничек яхшыларга юлдаш булып, Бәдбәхет усаллардан кач, зинһар.* М. Гафури.

СӨХБӘТЛӘШҮ *ф. иск. кит.* Сөйләшеп әңгәмә алып бару. *Күңел күтәренке вакытта сөхбәтләшү күңелле була.* М. Галәү.

СӨХБӘТЧЕ *и. иск. кит.* Сөхбәтләшеп-сөйләшеп утыручы, әңгәмәдәш. *Галимҗан матур итеп сөйли белә торган бик күңелле сөхбәтче иде.* А. Шамов.

СӨЮ *ф.* 1. Кул белән сыйпап, күкрәккә кысып, үбеп һ. б. ш. рәвешчә иркәләү, назлау, яратуыннышатуыңны белдерү. *Сабыйны кулга алып сөю. Олы балаларны башларыннан сөю. Аркадан сөю.* □ *Ана кулы сөеп үстергән дә, Киткән кеше тормыш юлыннан.* Г. Афзал. *Мин аны* [*бәрәнне*] *сөя, иркәли, сыпыргалый, матур сүзләр белән мактый идем.* Ф. Әмирхан. *Кичә генә әле иркәләде мине, Йомшак кулы белән чәчләремне сөйде* [*кыз*]. М. Җәлил.

2. Ярату. *Эш сөю.* □ *Димләгез кызның чибәрен, егет үзе сөйгәнен.* Җыр.

СӨЯК *и.* 1. Кеше, хайван тәнендә: скелетны тәшкил итүче каты җисемнәрнең берсе. *Баш сөяге. Калак сөяге. Бот сөяге. Сөяк сыну.* □ *Акбүз шалаш янныннан бер сөяк табып, тәмен белеп кенә кимерде.* Г. Гобәй.

2. *с. мәгъ.* Сөяктән яки сөяк катнаштырып эшләнгән. *Сөяк саплы пәке. Сөяк тарак.* □ — *Мә, теге сөяк саплы тамбур инәмне дә бирермен.* К. Тинчурин. *Сәхнәгә баянист чыкты һәм сөяк телләре җемелдәтеп торган зур баянда „Фронт янындагы урманда" көен башкарды.* Г. Әпсәләмов.

◇ **Сөяк йомшарту (йомшату, язу)** — 1) мунча кереп, физик күнегүләр ясап яки башка рәвешчә тәндәге авырлык, арганлык халәтен киметү яисә бетерү. *Ваннада сөякләрне йомшатып чыккач балалар белән бер чүкердәшеп чәй эчүләре ни тора бит.* М. Хәсәнов; 2) исерткеч эчемлек эчеп, тәндәге авырлык, арганлык халәтен онытып тору, шул тойгыны бастыру. *Бик соң кайттык, шуңа күрә бераз сөякләрне йомшартмый булмады. Беләсең бит, безнең эш авыр* [*дидә кызмача башлы эшче*]. А. Расих. **Сөяк утырту** — тайган сөякне кире үз урынына кайтару. *Минем әти карт — авылның яртысын салып биргән балта остасы, мич чыгаручы, ат дагалаучы, шуның өстәвенә, сөяк утыртучы иде.* Э. Фәйзи. **Сөяккә калу** — бик ябыгу, сөякләр беленеп торыр хәлгә төшү.

СӨЯКЛЕ *с.* 1. Сөяге булган, сөяктән арындырылмаган (ит турында). *Ашка сөякле ит салу.*

2. *к.* сөякчел. [*Авыру карт*] *миңа сул кулын сузды. Аның сөякле кулы ут кебек кызу иде.* М. Гафури.

СӨЯКЛӘНҮ *ф.* 1. Сөяк сыман булып катылану, сөяк хәленә килү, сөяккә әйләнү (кимерчәк һ. б. ш. турында).

2. Сөякчелгә әйләнү, сөякчелләнү. *Бармак сөякләнү.* □ *Мин әбиемнең җыерчыкланып, сөякләнеп калган шул кечкенә генә кулларын иң матур, иң йомшак диярмен идем.* Н. Дәүли.

СӨЯКЛӘЧ *с. к.* сөякчел. *Сөякләч җилкә.* □ *Хәйдәр аның таушалган йөзенә, гимнастеркасының кыска җиңнәреннән чыгып торган сөякләч һәм тар беләзекләренә борчылып һәм кызганып карап торды.* Г. Бәширов. [*Командующий*] *өстәлдәге Казан шәһәре планына бармак буыннарының сөякләч сырты белән төртә-төртә кайсы төбәккә нинди көчләр беркетелгәнен әйтте.* К. Нәҗми.

СӨЯК-САНАК, СӨЯК-САЯК *җыйд. и.* 1. Җанлы организмдагы, тәндәге сөякләр. *Сөяк-санак сызлап тору.* □ *Самат — матур, сөйкемле, сөяк-санагы да килешле яшь егет.* М. Фәйзи. [*Дворник:*] *Сөяк-саяк авыртып, йокыдан бик авыр торган идем.* М. Гали.

2. Итнең күбрәк сөякле, гадәттә түбәнрәк сыйфатлы кисәкләре. *Койка ясау өчен кибеттән сөяк-саяк алып кайту.*

3. Табыннан калган (итсез яки әз генә итле) яисә әллә кайчан ташланган сөякләр. *Эт-мәчегә сөяк-санак ташлау.* □ *Балалар аларны [көчекләрне] --- ашаганнан калган сөяк-санаклар белән сыйлыйлар.* Ак юл. *[Археологларның тирәсендә] кирпеч ватыклары, чүлмәк кыйпылчыклары, кибеп беткән сөяк-санаклар.* М. Госманов.

СӨЯКСЕЗ *с.* 1. Сөяге булмаган яки бик әз калган (ит турында). *Пилмәнгә сөяксезрәк ит алу.*

2. *күч.* Бик бөгелүчән-сыгылучан; хәрәкәтчән (гәүдә яки кеше турында). *Сөяксез гәүдәле акробат.*

◊ **Сөяксез тел** *шелт.*— күп, туктаусыз сөйләүчән тел яки жавапсыз сөйләүчән (гамәлгә ашмый торган сүзләр сөйләүче) кеше турында. *Сөяксез тел кайчак алдаса да, Күз карашы, жаным, алдамас.* М. Жәлил.

СӨЯКЧЕ *и. махс.* Сөяк-санак (3 мәгъ.) жыючы, хәзерләүче.

СӨЯКЧЕЛ *с.* Сөякләре нык беленеп торган, бик ябык яки чандыр. *Сөякчел бармак. Сөякчел гәүдә.* □ *Шундый тулы һәм олы гәүдәгә бөтенләй ятышсыз буларак, бик тә ябык, бик сөякчел иде бу кул, бүртеп-бүртеп торган зәңгәрсу тамырлы иде.* Р. Төхфәтуллин. *Аның саргылт, сөякчел йөзе ачудан кып-кызыл булды, иреннәре дерелди башлады.* И. Гази.

СӨЯКЧЕЛЛӘНҮ *ф.* Сөякчелгә әйләнү. *Кул сөякчеллəну.*

СӨЯКЧӘН *с. сир. к.* сөякчел. *Сөякчән кул.*

СӨЯЛ *и.* **1.** Тире өстенә үсеп чыккан, орлык зурлыгындарак каты төер; *русчасы:* бородавка. *Кул аркасына яки бармакларга сөял чыгу.* □ *— Менә сөялне кистерергә дә вакыт юк, үсә дә үсә!— дип ул муенында, ияк асты турында үскән сөялен тоткалап карады.* М. Максуд.

2. Аяк-кулдагы тиренең: озак эшләүдән, сыдырылудан бирчәю сәбәпле кабарыбрак һәм катыланып калган урыны; *русчасы:* сухая мозоль. *Париж палачлары атылачак корбаннарының Коммуна яклымы әллә түгелме икәнлекләрен аларның кулларында сөял булу-булмавына карап билгеләгәннәр.* С. Баттал. *Табаннарга сөял чыкса да, Күкрәгемне камыт кысса да, Алга атлыйм әле һаман да Илем белән якты заманга.* Каз. утл.

◊ **Сөялгә басу** — берәүнең аеруча борчыган, күңеленә тия торган ягына кагылу, шул кимчелеккә ишарәләп төрттерү, шул яктан борчу ясау. *Тормыш укымаган кешенең сөяленә бик тиз баса.* Г. Әпсәләмов.

СӨЯЛЛЕ *с.* Сөяле булган, сөял үскән яки чыккан. *Сөялле бармак. Балта остасының сөялле кулы.* □ *[Кызның] кулы этисенең сөялле учына чумды.* Ш. Хөсәенов.

◊ **Сөялле кул** — 1) эшче, хезмәт иясе кулы турында. *Сөялле бу кул авыраймас эштән, Ул ямь-тәм таба мөкатдəс эштән.* З. Байчурина; 2) эшче, хезмәт иясе турында. *Сарайларны балалар йортларына һәм сөялле кулларның ял итү йортларына әйләндерү юлында --- асылган революционерлар искә төште.* М. Максуд. **Сөялле куллы** — *к.* сөялле кул (2 мәгъ.). *Сөялле куллы, сизгер күңелле эшче шагыйрь дә аның үлгәнен ишеткәч, зур бер әсәр язарга уйлады.* Ф. Әсгать.

СӨЯЛЛӘНҮ *ф.* Сөяллегә әйләнү. *Уч сөялләнү.* □ *Гатаулла, буыннары сөялләнеп беткән тупас бармаклары белән сакал астын кашыды.* А. Расих. *Салмак кына, иренеп басалар Сөялләнгән авыр аяклар.* Ә. Маликов.

СӨЯЛҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сөяү.

2. Берәр нәрсәгә яки кешегә якын ук килеп яисә утырып, гәүдәнең югарыгы өлеше белән аңа терәлү, таяну. *Капка баганасына сөялү.* □ *Салават ашыкмый гына урынныннан торып утырды, аркасы белән стенага сөялде.* А. Шамов. *Газизә байтак вакыт, ишек яңагына сөялгән көе, китеп баручылар артыннан карап торды.* Ш. Камал.

СӨЯМ *и. иск.* Аршынның чирегенә тигез үлчәү берәмлеге. *Ике-өч сөям тирәнлеге кар.* □ *Арышлар, бодайлар --- куе, камыш шикелле эре камыллы, берәр сөям башаклы, бөгелеп, каерылып бетеп уңалар икән.* М. Гали.

СӨЯМЛЕ *с. иск.* Сөямнәргә бүленгән, сөямнәр белән үлчәү өчен яраклаштырып эшләнгән (таяк һ. б. ш. турында).— *Бу турыда бит агым ай-яй кызу! Су төбендә ком түгел таш чыдамый. Бүтән берәү булса сөямле таяк белән үлчәп йөрер иде. Атаң алай итми. Атаң суны үтә күрә. Төбенә хәтле.* К. Нәҗми.

СӨЯН *и.* **1.** Кайрысы, кабыгы төшерелгән юкә бүрәнәсе. *Сөян утыны. Сөян йомычкасы. Мунчала күле буеннан сөян ташу.* □ *Монда агач кытлыгы; йортларны сөяннән, усактан салганнар.* Г. Ахунов.

2. *с. мәгъ.* Кайрысы, кабыгы төшерелгән (юкә бүрәнәсе турында). *Сөян бүрәнә.* || Сөян бүрәнәдән салган, эшләгән. *Сөян бура. Сөян терәү кую.* || Сөян бүрәнәне ярдырып эшләгән, алынган. *Сөян рамлык. Сөян такта.* □ *Юа торгач юкарып беткән сөян баскычта салып калдырган аяк киемнәре тора.* Каз. утл. || Гомумән, сөяннән эшләнгән, алынган. *Сөян шакмак. Сөян арата.*

СӨЯРКӘ *и. хурл.* Өйләнешмичә, мораль-әдәп нормалары белән исәпләшми жәнси мөнәсәбәттә торучыларның һәркайсы. *Сөяркә тотучы байлар.* □ *Бу яшерен серне --- Зөһрә апа үзенең сөяркәсе Гафургә әйткән имеш.* Г. Ибраһимов. *Көнчебану, сөяркәңә телефоннан шалтыратасың икән дип, үзенең хәлəл жефетен тинтерәтә ди.* Мәзәк.

СӨЯҮ *ф.* Авып төшмәсен өчен гадәттә югарыгы ягы белән берәр нәрсәгә терәп кую. *Көрәкне сарай почмагына сөяү. Баскычны яткырып койманың эчке ягына сөяп тору. Багор-пумалаларны өй буена сөяп кую. Бастырып яки утыртып сөяү.* □ *Габиш имән төбенә сөягән таягын кулына алды.* Ф. Кәрим. *Ильяс әмәлен тапты. Арбага сөзәкләп таза гына ике такта сөяп куйды, капчыкларны кар йомрысы күк итеп шуннан тәгәрәтеп менгезергә тотынды.* Р. Төхфәтуллин. || Ышыклау-каплау максаты белән шул рәвешле кую. *Лапас авызына такталар сөяү. Абзарның җил үтәрдәй ярык турыларына кабык сөяү.* || Баскан яки утырган хәлдәге гәүдәне: берәр җиргә терәү. *Искәндәр бу юлы Маратны ятырга кыстамады, мендәрен карават рәшәткәсенә иплəп куйды да шуңа сөяп утыртты.* Г. Гобәй. *Катя җылы мичкә аркасын сөяп китап укый.* Г. Әпсәләмов.

СӨЯҮЛЕ *с.* Сөяп куелган. *Сөяүле тырмага абыну.*

СӨҢГЕ *и.* **1.** Озын нечкә саплы чәнчү коралы (ауда һәм сугышта кулланылган). *Хан гаскәре, бер юлы кузгалып, сөңгеләре белән Жик өстенә килә башлый.* М. Жәлил. *Йонлач бурка бөркәнгән, сөңге тоткан ике атлы урам буенча чабып узды.* И. Гази.

2. Сөңгегә охшаш нәрсә. *Малайларның сөңге белән боз тишүе. Язга таба өй кыегыннан боз сөңгеләре салынып төшә башлау. Биек тауның сөңгесен штурмлау.* □ *[Мәскәү Кремленең бер капкасы] кечкенә почмак манараларының, озын нечкә сөңгесе белән яңадан эшләнә.* Сов. эд.

СӨҢГЕЛЕ *с.* Сөңгесе булган, шуның белән коралланган. *Җәяүле һәм сөңгеле сакчылар мәйданны уратып алганнар.* Әкият.

СӨҢГЕЛӘНҮ *ф.* Сөңге сыман очлау, сөңгегә охшау. *Өй кыегыннан салынып төшкән бозларның сөңгеләнеп торуы.*

СӨҢГЕЧЕ *и.* 1. Сөңге белән коралланган сугышчы. *Сөңгечеләр чәнчү өчен бердән сөңгеләр күтәрәләр.* Н. Исәнбәт.

2. *спорт.* Сөңге (1 мәгъ.) спорты белән шөгыльләнүче, сөңге ярышында катнашучы.

СҮГЕНҮ *ф.* Үз алдына сөйләнеп сүгү. *Камали чыккан саен базардан сүгенеп кайта:— Харап бу спекулянтлар!— ди.* Г. Ибраһимов. *Ир бар, болай „чын ир", үзе әйтмешли: Исереп кайта, сүгенеп сөйләшә.* М. Җәлил.

СҮГЕШ *и.* Сүгү, сүгенү фигыльләреннән ясалган исем. *Сүздән сүз чыгып, [эш килешүчеләр арасында] сүгеш китте.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

2. Сүгү, сүгенү сүзләре. *Дни бер вакыт ни өчендер асрауны кыйнады; шул вакытта Фәхерниса елады... елады; шуның өчен әнидән үзенә әллә ни кадәр шелтә, сүгеш ишетте.* Ф. Әмирхан. *Күтәрдем зур сабыр берлән сүгешләрне, каһәрләрне!* Н. Исәнбәт.

СҮГҮ *ф.* Хурлау сүзләре әйтеп тиргәү, шелтәләү, тәнкыйтьләү. *Искәндәр үз уйлары белән мәшгуль. Ул үзен сүгә: --- Тиле мин, тиле,— ди.* Г. Гобәй. *Ул шәһәр тормышын сүгә.* Г. Нигъмәти.

СҮЗ *и.* 1. Бер яки берничә аваздан төзелеп мәгълүм грамматик форма алган (сөйләмдә җөмлә кисәге яки җөмлә булып кулланыла торган) һәм төшенчә белдерә торган иң кечкенә лексик берәмлек. *Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч кушымчалар. Туры яки күчмә мәгънәле сүзләр. Кушма сүз.* □ *Мөстәкыйль сүзнең нәрсәне булса да аңлата торган, үзенә хас мөстәкыйль мәгънәсе була.* В. Хангилдин. *Ул чагында инде лордлар булмас; Архаизм булыр „лорд" сүзе; Буржуй дигән сүз дә кабатланмас, Нәселе беткән булыр планетада.* Н. Баян. || Бер яки берничә аваздан төзелеп, логик яки грамматик мөнәсәбәтләрне белдерә (сөйләмдә җөмлә кисәге дә, җөмлә дә була алмый) торган иң кечкенә лексик берәмлек. *Ярдәмлек сүз.*

2. Сөйләшү, әңгәмә; сөйләп бирелә торган фикер. *Сүзгә катнашу. Сүзгә керешү. Сүзне икенчегә бору. Сүзгә оста булу. Сүзне бүлү. Берәр нәрсә турында сүз алып бару.* □ *Шәйхаттар бабай башлаган сүзен бетермичә туктамады.* Г. Гобәй. *Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя.* Г. Тукай. *Эшкә оста, сүзгә кыска,— һәркем аны ярата.* Ә. Исхак.

3. Җыелышта һ. б. ш. җирдә: телдән ясала торган чыгыш. *Сүздән туктату. Соңгы сүз белән чыгу.* □ *Пленумда докладчылар булсын, доклад буенча сүз алучылар булсын, барысы да ачык фактлар белән бездә әдәбиятның зур үсүгә ия булганын әйттеләр.* М. Җәлил.

4. Сөйләү хокукы. *Сүз иреге даулау.*

5. Фикер, караш; бәяләмә. *Менә сиңа бер үк мәсьәләгә карата ике фикер: берсе — алдынгы фән сүзе, икенчесе — авторитетлы практика нәтиҗәсе.* М. Хәсәнов. *Көчәндең, көчкә аңлаттың сүзеңне!* Дәрдмәнд. *Сәламәт тәндә сәламәт җан дигән сүзнең бик дөрес булырга тиешлеген уйлап ала ул.* Ә. Еники. *Ул һаман үз сүзендә калды.* Ф. Әмирхан.

6. Киңәш, тәкъдим һ. б. ш. *Олылар сүзен тоту. Кеше сүзенә карау.* □ *Әтиең үләр алдыннан әйтте бит үзеңә: анаңның сүзен тыңла, кушканын үтә, диде.* И. Гази. *[Әтисе, улына укуын ташларга кушып:] Менә, Газиз, сүз шул сиңа.* Ф. Әмирхан.

7. Шелтә, тәнкыйть, гайбәт һ. б. ш. *Нәрсәгә соң Миңнурый бу кадәр ярсыган? Мөгаен, сүз ирештергәннәрдер дип уйлап алды Газинур.* Г. Әпсәләмов. *— Сиңа андый-мондый сүзләр, гайбәтләр сылтанудан курыктым.* Ш. Камал.

8. Вәгъдә. *Сүз куешу. Сүздә тору.* □ *[Эшеңне] шимбәгә китереп җиткер дип сүз алдылар.* Г. Ибраһимов. || Ант.— *Мин ант итеп әйтәм, ышан, сөеклем. Гомердә дә мин сүземнән кайтачак түгелмен. Әгәр кайтсам, --- телем корысын.* А. Шамов. *Улгәндә дә хәтта бу җирдән Чигенмәскә алар сүз биргән.* Ә. Исхак.

9. *күпл. форм.* Музыкаль яки шигъри әсәр тексты. *[Мансур:] Ошады. Җиңел көй. Ашкынулы көй. Уңышың белән котлыйм, котлыйм, Наилә! --- Ә сүзләре кемнеке? [Наилә:] Анысын да үзем яздым.* Р. Ишморат.

10. *с. мәгъ.* Бер сүз белән генә белдерелә торган. *Сүз җөмлә.*

◇ **Сүз алышу** — кара-каршы сөйләшеп алу, фикер алышу. *Сораучылар тагы әллә ни чаклы сораулар биреп җавап алганнан соң һәм үзара бераз сүз алышканнан соң:— Бар, хәзергә казармага кайтып тор,— дигән сүзләрне әйтеп, Вахитны чыгарып җибәрделәр.* М. Гафури. **Сүз ара (артыннан) сүз чыгу** — *к.* сүз иярә сүз чыгу. *Сүз ара сүз чыгып, землемер аңа:— Гомәр, сез үзегезнең гали мәдрәсәдән кем булып чыгасыз?— диде.* Ш. Камал.— *Ярар, Газинур улым. Сүз артыннан сүз чыга. Дзрәк черем итеп алырга да кирәк.* Г. Әпсәләмов. **Сүз арасында** — 1) бүтән сүзләр белән бергә, шулар рәтеннән, шуларга кушып. *Укый-укый, сүз арасында кайбер китап сүзләре дә кыстырып җибәргәләү дәрәҗәсенә иреште [Гәрәй].* М. Әмир; 2) башка нәрсә турында сөйләгән сүзләргә кушып, бер уңайдан. *Без төрлесеннән аз-маз сөйләшеп алдык. Сүз арасында кемнең кайда эшләве, ничек эшләве, ничек көн үткәруе дә беленде.* К. Басыйров; 3) сөйләшкән арада, шул вакытта. *Сүз арасында самовар тагын яңартылды.* К. Нәҗми. **Сүз башы** *махс.*— берәр әсәргә язылган кереш сүз, китаптагы кереш мәкалә. *[Г. Камалның] революциягә кадәр язган публицистик һәм тәнкыйть мәкаләләрендә генә төрекчелек тәэсире беркадәр сизелә. „Бәхетсез егет"нең икенче басмасына язган сүз башы моңа ачык мисал булып тора.* М. Гали. **Сүз белән сыйлау** *ирон.*— 1) кунакны, сыйлыйсы урында, сүз белән мавыктыру; 2) тормышка ашмастай, буш, ялган вәгъдәләр бирү; эшне сүз белән алмаштыру. *[Солдатлар— Вакытлы хөкүмәт агитаторына:] Ә кайчан өйгә кайтабыз? --- Безне сүз белән күп сыйладыгыз, эшегезне күрмибез.* Ф. Хөсни. **Сүз бер булу** — 1) әйткән сүздә тору, аннан кайтмау, аны үтәү. *Егет сүзе бер булыр.* Мәкаль. *Яратасың икән ярат, яратмыйсың икән — кара аны! Минем сүзем бер булыр!* Ә. Камал; 2) бер сүздә, бердәм булу. *Җир эшләрендәге спецлар белән Вәли Хәсәновның сүзе бер. Болар, һәммәсе берләшеп, алпавыт Алексейның байлыгын арттырмак булалар.* Г. Ибраһимов. **Сүз берегү** — бердәмлеккә ирешү, бер сүздә булып китү. *Булса да сүзләр береккән, Бу өчәү [Арыслан, Юлбарыс һәм Мәче] аерым яши.* Г. Тукай. **Сүз беркетү** — килешеп, сүз куешу; вәгъдәләшү.— *Ярышырга дип сүз беркеткәнбез икән, алардан [күршеләрдән] артка калу безгә төс булмас.* Г. Бәширов. **Сүз берләшү** — бердәм эш итү турында сөйләшеп кую, килешү. *Фәтхия кодагый белән Хәерниса кодагый, бу турыда сүз берләшкән кебек, бер уңайдан, бер якка таба сөрделәр.* Г. Ибраһимов. **Сүз бистәсе** — *к.* тел бистәсе.— *Әй мин, сүз бистәсе, самовар турында бөтенләй онытканмын.* И. Гази. **Сүз булсын дип (өчен генә)** — сөйләми калырга теләмәгәннән яки ярамаганнан, болай гына. *— Минем саргайганым юк. Суксам иңнәрен сындырырлык тазалыгым бар, моны тик сүз булсын*

дип лыгырдыйлар инде. Г. Ибраһимов. **Сүз буткасы** *шелт.*— 1) эш эшлисе урында сөйләнә торган, файдасыз сүзләр, лыгырдаулар. *Сүз буткасы белән гомер үткәрергә ярамый.* Г. Ибраһимов; 2) бәйләнешсез сүзләрдән торган, мәгънәсе ачык булмаган сөйләм. [*Начар җавап бирүче укучыдан*] *мәгънәсез сүз буткасы ишетеп, бөтен класс көлә башлады.* А. Тимергалин. **Сүз буткасы пешерү (куерту, кайнату, ясау)** — 1) бәйләнешсез яки мәгънәсе ачык булмаган сүзләр сөйләү. *Сорауның бернинди фикергә корылмаган, кара мужикларның күзләренә төтен җибәрер өчен генә кайнатылган сүз буткасы икәнен бер шәкерт төшенеп өлгермәде ахры, каршы төште.* Ә. Фәйзи; 2) эшне сүз белән алмаштыру, лыгырдау, күп сөйләү. *Җыелышны бик ошаттым... Чөнки артык сүз буткасы куерту булмады.* Ш. Камал. **Сүз иярә сүз чыгу (китү), сүздән сүз чыгу (китү)** — бер фикер, әйтелгән сүз уңае белән икенчесен телгә алу. *Бер көнне без, әбәттән соң ял итеп утырганда, сүз иярә сүз чыгып, кошлар турында сөйләшә башладык.* Ф. Хөсни.— *Сүздән сүз чыгып, мин Кигәвенлегә, коммунага эшләргә барачагымны белдердем.* Ш. Камал. *Сүз иярә сүз китте. --- Һәммәсе дә телгә алынды.* Г. Бәширов. **Сүз йөртү** — берәүнең сүзен икенче кешегә җиткерү, гайбәт ташу. *Мәгъри өйдән өйгә йөреп гайбәт тарата, сүз йөртә.* М. Гали. **Сүз кайтару** — 1) ризалашмыйча-килешмичә, каршы сүз әйтү, каршы килү. *Без карышмадык, бер сүз кайтармадык.* Г. Тукай; 2) гомумән, җавап кайтару. *Гадәттә ике авыз сүз дә кайтарып әйтә алмый торган мескен, йомыкый кешенең кинәт кенә кабынып китүенә --- Садыйк абзый чын-чынлап гажәпкә калды.* Н. Фәттах; 3) берәүнең үтенечен кире кагу, сүзен канәгатьләндермәү. *Мондый кеше өмә итсә, бик үк ялгыз булмаганнар сүз кайтарырга килештермиләр инде. --- Барабыз-барабыз дип атылып торалар.* Г. Ибраһимов. **Сүз килешү** — сер килешү. *Алиш аның Казанда чактагы үк иптәше, сүз килешә торган кешесе иде.* Ш. Маннур. **Сүз кушу (кату)** — 1) берәүгә эндәшеп, сүз башлау. *Кырыйдагы урындыкта утыручы хатын әледән-әле балаларга сүз ката, исемнәрен, яшьләрен сораша.* Г. Минский. *Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан.* А. Алиш; 2) тәкъдим ясау; сүз, сер салу. *Давыт үз эти-әниләре белән сөйләшеп тә куйган бугай инде, ләкин Гөлзифаның әле бу турыда әнисенә бер кәлимә сүз дә катканы юк.* Р. Төхфәтуллин. *Яратмасам, яучылар аркылы сүз кушмас идем.* Г. Толымбай. **Сүз көрәштерү** — бәхәсләшү. *Карт улының табигатен яхшы белә иде, сүз көрәштерүнең файдасызлыгын аңлады.* Г. Ибраһимов. **Сүз рәте (уңае, җае) белән, сүз рәтендә (уңаенда, җаенда)** — башка сүзләр белән берәттән, сүз арасында. *Сүз рәтендә бер сүз әйтәм, туктагыз!* Ш. Бабич. [*Жандарм*] *сүзне икенчегә күчерде.* — *Ярый. Бәлки шулайдыр. Ул кечкенә эш. Мин аны сүз уңаенда гына әйтәм.* Г. Ибраһимов.— *Д менә эшнең авырлыгын, тормышның начарлыгын, эш хакының аз икәнлеген һәм башка шуның ише хәлләрне сүз җае белән һәр җирдә, һәр кешегә тукырга мөмкин.* Ш. Камал. **Сүз салу** — берәүне нәрсәгә дә булса өндәп, сорап, тәкъдим итеп сүз кушу; тәкъдим ясау. *Авылда Рәүфәгә күз ташлаган, сүз салган егетләр дә юк түгел иде.* А. Шамов. **Сүз уйнату** — 1) уенкөлке сүзләр сөйләп шаяру. [*Габдулланың*] *„Үсәдер кызлар әнкәсе куенында“ дигән сүзләре шәкертләрне кызлар мәсьәләсенә күчеп җорланырга, кыю-кыю гына сүз уйнатып алырга мәҗбүр итте.* Ә. Фәйзи; 2) *шелт.* сөйләмнең эчтәлеге өчен әһәмиятсез яки аз әһәмиятле, ләкин матур, купшы һ. б. ш. сүзләр белән мавыгу. *Шигырьдә матур сүзләр уйнатудан мәгънәгә күчү дәвере килде.* Һ. Такташ; 3) *шелт.* берәр фактны йомып калдыру өчен күперенке буш сүзләр куллану, шаярткан булу, риядан сөйләү һ. б. ш. *Кыз әле болай боргаланды, әле тегеләй сүз уйнатты.* С. Рафиков. *Болар бары да сүз уйнату, сәбәп эзләү генә, иптәш директор,— диде Иштуган.* Г. Әпсәләмов; 4) *лингв.* контекст эчендәге берәр сүзнең яки тәгъбирнең бер үк вакытта ике мәгънәдә аңлашылуына нигезләнгән шаярту алымы. **Сүз эштән аерылмау** — әйткән сүздә тору, йөкләмәне, вәгъдәне үтәү. *Механизаторлар яңа елга --- ремонтны төгәлләргә сүз бирделәр. Сүз эштән аерылмый. Колхозда ремонт зур оешканлык белән бара.* Соц. Тат. **Сүз югында (югыннан) сүз булсын дип (өчен)** — *к.* сүз булсын дип. *Шактый вакыт сүзсез барганнан соң, Гаяз, сүз юктан сүз булсын дигән сыман гына итеп, миңа сорау биреп куйды.* М. Әмир. **Сүз эзләп (өчен) кесәгә (кешегә, күршегә) кермәү; сүзгә кешегә чыкмау һ. б.**— сүзгә, җавапка бик оста, тапкыр булу. *Матвеич сүз эзләп кесәгә керми.* К. Нәҗми. *Директор сүз өчен кесәгә керә торган кеше түгел иде.* К. Басыйров. *Андый сүзләргә кесәгә кереп азапланмый инде ул Шәми.* Р. Төхфәтуллин. **Сүз җилеме** — 1) сүз булсын өчен генә әйтелә торган сүз, сөйләм. *Сүз җилеме булсын дигән кебек, Илфар белән Кадим баштарак җыен вак-төякне сөйләшеп утырдылар.* Б. Камалов; 2) оста сүз, шаян сөйләм турында.— *Онны илиләр, сүзне сөйлиләр, батырны үстерәләр, куркакны постыралар, сүз арасына җилем кыстыралар.* Ә. Фәйзи; 3) *лингв.* сүзне җанландыра торган шаяртулы рифмалар кулланып яки эчтәлексез шаян җаваплар тезеп, сөйләмгә шаярту төсмере бирү алымы. **Сүзгә килү (килешү)** — ызгышу.— *Бүген Хәсән белән бик каты сүзгә килештек.* Г. Әпсәләмов. *Шиһапов берәү белән дә сүзгә килмәскә, барлык кеше белән дә тату булырга тырыша.* И. Гази. **Сүздә генә калу** — сөйләнеп тә эшләнмәү, тормышка ашмау. — *Сүздә генә калмасын иде бу. Һәйкәлләр вәгъдәләрдән куелмый.* Г. Әпсәләмов. **Сүздән түбән** — тәнкыйтьтән түбән. *Үзләре... сүздән түбәннәр, күзләре тездән түбән; Эт кеби һаулап яманым, күз йомалар яхшыма.* Г. Тукай. **Сүздән чыкмау** — сүз тыңлау; сүзне, вәгъдәне бозмау.— *Ана сүзеннән чыкмый торган улым ул минем Нәфис.* А. Әхмәт.— *Кәфа аны, минем сүздән чыгасы булма.* Г. Камал. **Сүзне бирмәү** — 1) бәхәстә, сүз көрәштерүдә: җиңелмәү. *Котып үзсүзле кеше иде. Сүзен бирмәскә теләп, төрлечә сөйләп карады. Ләкин Гасыйм белән Батыр солдат каршында аның һәрбер сүзе аска кала килде.* Х. Садрый; 2) әйткән сүздән кайтмау; килешмәүчәнлек күрсәтү, ташлама ясамау. *Мин үз сүземне бирмим. Китәм булгач китәм, дим.* Ф. Хөсни. **Сүзне (сүзеңне) итү** — сүзне үтәү; сүздә тору.— *Мортаза бәлки хатынының сүзен итәр өчен баргандыр.* Ш. Камал. **Сүзне сүз итү** — каршылыкларга карамастан, сүзеңне, тәкъдимеңне, фикереңне тормышка ашыру, үз дигәнеңдә тору.— *Монда да үз сүзебезне сүз иттек.* Н. Исәнбәт.

СҮЗГӘ-СҮЗ *рәв.* 1. Ишеткәнне, укыганны сөйләү-сөйләтү, язу-яздыру турында: дөп-дөрес һәм төп-төгәл, бер сүзен дә төшерми-төшертми һәм бутамый-буташтыртмыйча. *Берәүнең әйткәнен үзеннән сүзгә-сүз кабатлату. Лекцияне сүзгә-сүз дип әйтерлек язып бара алу.* □ *Ул бер тапкыр укыган китапны ятлап сүзгә-сүз сөйләп чыга ала.* Г. Кашшаф.

2. Тәрҗемә ителгән телнең һәр сүзен һәм аларның эзлеклелек тәртибен тәрҗемәдә дә саклап; формаль, механистик рәвештә (тәрҗемә итү турында). *Насыйри*

заманында күбесенчә сүзгә-сүз тәрҗемә итә торган иделәр. Ш. Рамазанов.

СҮЗЛЕ *с.* **1.** *сир.* Күп сөйләшергә яратучан; сүзчән. *Сүзле кеше.*

2. Ызгышлы, гаугалы, тавышлы. *Бик сүзле булды бу эш.*

3. *махс.* Көе генә түгел, сүзләре, тексты да булган (музыка әсәре турында). *Сүзле музыкалардан тыш, җыентык ахырында фортепианода башкару өчен өч инструменталь [уен коралында башкара торган] әсәр бирелде.* М. Җәлил.

СҮЗЛЕК *и.* **1.** Сүзләрне, идиомаларны һ. б. кайбер төр тәгъбирләрне җыеп, алфавит тәртибе белән яки бүтәнчә урнаштырып, аларга тиешле аңлатмалар яки тәрҗемәләр биргән китап, белешмәлек. *Аңлатмалы сүзлек. Ике телле, яки тәрҗемәле сүзлек. Идиомалар сүзлеге. Мәкаль-әйтемнәр сүзлеге. Диалектологик сүзлек. Этимологик сүзлек. Орфография сүзлеге. Энциклопедик сүзлек.*

2. *җый.* Берәр телнең, язучының яки әсәрнең барлык сүзләре. *Татар теленең сүзлек составы.*

СҮЗЛЕКЛӘШҮ *ф.* Телгә керү, сүзлек берәмлегенә әйләнү (сүзләр, тәгъбирләр турында).

СҮЗЛЕКЧЕ *и.* Сүзлек эшләүче фәнни хезмәткәр; сүзлек белгече; лексикограф. *Сүзлекче кадрлар хәзерләү.*

СҮЗЛЕКЧӘ *и.* Кечкенә сүзлек. *Дәреслек ахырында бирелә торган терминнар сүзлекчәсе.*

СҮЗЛӘНЕШҮ *ф. сир.* Ызгышу, сүзгә килешү. *Балалар үзара сүзләнешеп, икесе ике сукмактан киткәннәр.* С. Әдһәмова.

СҮЗЛӘП *рәв.* Сүзләрне аерым-аерым әйтеп, һәр сүз саен тукталыш ясап (уку һ. б. ш. турында). *Сүзләп яздыру. Сүзләп кенә уку.*

СҮЗЛӘШҮ *ф.* Каршы әйтү, әрепләшү. || Ызгышу, сүзгә килешү.— *Сезнең белән бик каты сүзләшергә туры килә бит.* Чаян.

СҮЗМӘ-СҮЗ *рәв. к.* сүзгә-сүз. *Ишеткәнне сүзмә-сүз сөйләп бирү. Сүзмә-сүз тәрҗемә.*

СҮЗСЕЗ *с.* **1.** Сөйләшмәүче, сүзгә катнашмаучы. *Шигырьләрне укыганда күз алдында тын һәм һәрбер сүзне аңлап калырга омтылган сүзсез залны күрәсең.* һ. Такташ.

2. Күп сөйләргә гадәтләнмәгән, аз сүзле. *Безнең үзебезгә сүз башлавы, билгеле, кыенрак иде, аннары нидер менә телебезне һаман бәйләп тора иде. Ләкин гаҗәп хәл: хуҗалар үзләре дә сүзсезләр иде. Гомумән, бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк, ничектер бик тиз без шуны сизгәндәй булдык.* Ә. Еники. || Каршы әйтергә гадәтләнмәгән, күндәм, карусыз. *Бу килен сүзсез, талашсыз булып чыкты, кара эшкә гаҗәп батыр иде.* Г. Ибраһимов.

3. Сөйләмичә генә уйнала-башкарыла торган (спектакльдәге күренешләр һәм артист роле турында). *Сүзсез күренешләрдә катнашу. Сүзсез рольләрне уйнау.* □ *Спектакль куйган чакта аңа эшчеләр ролен бирәләр. Гадәттә бу роль сүзсез була: Салих җиңнәрен сызганып, мускулларын уйнатып сәхнәне арлы-бирле узгалап йөри.* И. Гази. || Сүзләр әйтмичә, сөйләмичә генә уйнаучы (артист турында).

4. Сүзләре-тексты булмаган, көй рәвешендә генә җырлана-уйнала торган (җыр, музыка әсәре турында). *Сүзсез музыка.*

5. *рәв. мәгъ.* Сүзләр әйтмичә, сөйләшмичә. *Сүзсез дә аңлашылу. Сүзсез генә елау.* □ *Искәндәрев Хәнифә ханым белән сүзсез генә баш иеп исәнләште.* Ә. Еники. *Чыннан [яратышуларны Сүзсез сизә яшь күңел.* Ф. Кәрим.

6. *рәв. мәгъ.* Каршылык-ризасызлык күрсәтмичә. *Бу ике көчнең соңгысы җиңәчәген күңелем бик ачык сизсә дә, мин сүзсез генә бирелергә теләмәдем.* М. Әмир.— *Һәммәсе дә сиңа йөкләнәләр!.. Сүзсез эшләү синең бурычың.* М. Гафури. || Вакчылланмыйча-төпченмичә, бик тиз килешеп. *Бу бәетләрне урамнарда кычкырып җырлап йөри башлагач, ике як та сүзсез, әллә нинди мәһәрләр-фәләннәр турында сөйләшеп тормыйча ук, безне өйләндермәкчеләр иде.* Г. Ибраһимов.

СҮЗСЕЗЛЕК *и.* **1.** Аз сүзле булу сыйфаты, күп сөйләргә яратмаучанлык. *Кружкаларны бер-ике күтәргәч --- телләребез ачылды. Хәтта сүзсезлеге, дөресе, бик аз сүзле булуы белән дан алган ефрейтор Сәмигуллин да --- нәрсәдер сөйләп алды.* А. Шамов. || Ызгышырга гадәтләнмәгәнлек, күндәмлек, карусызлык.

2. Сөйләми-сөйләшми тору хәле. *Булат сеңлесенең такылдавын бүлдерде дә шунда сүзсезлектән, эшсезлектән кыенсынып газапланып утырган Җиһангирга борылды.* Г. Ибраһимов.

СҮЗСЕЗЛӘНҮ *ф.* Бик аз сөйләшүчән булып китү, аз сүзлегә әйләнү. *Корбангали абзый, юлга чыккач, телен йоткандай булып сүзсезләнә.* Ф. Хөсни.

СҮЗЧӘН *с.* **1.** Күп сөйләргә яратучан.— *Син өченче ел шундый сүзчән, хәрәкәтчән идең.* Ф. Әмирхан. *Шәймәрдән абзый үзе сүзчән булса да, аның янындагы --- күзлекле берәү юл буенча „әйе"дән башка бер сүз дә әйтмәде.* К. Нәҗми.

2. Ызгышырга яратучан.

СҮЗЧӘНЛЕК *и.* Сүзчән кешегә хас сыйфатлар. *Аның болай сөйләргә ярату дәвере минем яшь чагымда гына булып, мин тугыз-ун яшьләргә җитеп сабак укый башлагач, сүзчәнлек вә ачыклыгы сүнә башлады.* Ш. Камал.— *Мин үзем сүзчән егет. Сүзчәнлегем өчен бәлагә дә эләктем.* К. Нәҗми.

СҮЗЧӘНЛӘНҮ *ф.* Сүзчәнгә әйләнү. *Ул терелеп килүче башка авырулар белән бергә көлә, шаяра, сүзчәнләнеп, рәхәтләнеп озак кына сөйләшеп утыра.* А. Шамов. *Гайсаның борын очы кызара, күзләре бераз канланып ялтырый, үзе дә көләч һәм сүзчәнлә бара иде.* Ф. Әмирхан.

СҮЛ *и.* Үлән, хайван, кеше организмы күзәнәкләрендә, күзәнәк араларында, тукымаларында була торган сыекча. *Кулга үлән сүле сеңү. Итнең сүле сарку.* □ *Башаклар көч, хәят, шатлык сүлләре белән тулганнан-тула бара.* Р. Төхфәтуллин. *Ашказаны сүлендә ул [ясалма азык таблеткасы] --- витаминнар һәм минераль тозлар барлыкка китерә.* А. Тимергалин.

СҮЛЛЕ *с.* Эчендә сүле булган; сүле күп булган. || Сүл белән аралашкан, сүл катнашкан (сыеклыклар, сыекчалар турында).

СҮЛЛӘНҮ *ф.* Эчендә сүл барлыкка килү, сүллегә әйләнү; сүле күбәю, арту. *Аның балтыр сөягендәге иске ярасы ачылган, эренләп, сүлләнеп тора.* Х. Камалов.

СҮЛПӘН *с.* **1.** Киереп тарттырылмаган, буш, салынкы (тарттырып куйган бау, җеп, тимер чыбык һ. б. ш. турында).

2. Нык катылмаган, җитәрлек бөтерелмәгән, тыгыз түгел (катылган җеп һ. б. ш. турында).

3. Бик әкрен; җитез түгел (хәрәкәт турында). *Сүлпән адым.* □ *Аңа врачларның хәрәкәтләре искиткеч акрын һәм сүлпән кебек тоелды.* Ш. Хөсәенов.

4. Бик басынкы, ихтыярсыз, кыюсыз (кеше, аның табигате турында). *Газимә ничектер бик сүлпән иде, кыюсыз иде.* Н. Фәттах. *Боек, сүлпән, омтылышсыз була Хыялсыз көн иткән һәр кеше.* Ф. Кәрим. *Шуның ише сүлпән табигатьле кешенең гаилә төзеп, нигезле рәвештә көн күрү бусагасына аяк басуы үзе*

генә дә, гомумән, тормыш яхшыра барганлыкны ачык күрсәтә. Ш. Камал. || Бик салынкы, сүлпәнлекне күрсәтә торган (кыяфәт, сүз һ. б. турында). *Сүлпән холыклы кеше.* □ *Бүген инде аның кыяфәте сүлпән түгел иде.* Г. Ахунов.

5. *рәв. мәгъ.* Бик әкрен, салмак темп белән (эшхәрәкәт итү турында). *Сүлпән эшләү. Сүлпән хәрәкәтләнү.* □ *Акрын гына, сүлпән генә Мин өемә атладым.* М. Җәлил. *Нәфисәгә машина бик сүлпән әйләнә кебек тоела башлады.* Г. Бәширов.

СҮЛПӘНЛЕК *и.* Сүлпән (1—2 мәгъ.) булу сыйфаты, рәвеше. *Җепнең сүлпәнлеге.* || Сүлпән (3—5 мәгъ.) булу хәле, халәте. *Хәрәкәт сүлпәнлеге. Эшнең сүлпәнлеге. Спектакльнең сүлпәнлеге.* □ *Аның йөрешторышындагы сүлпәнлек-кыюсызлыкларын уйлап, командир ни әйтергә дә белмичә аптырабрак тора иде.* А. Әхмәт. *Әле иртәнге алты гына булса да, хәзер аның йокысы да, сүлпәнлеге дә качкан иде.* А. Расих.

СҮЛПӘНЛӘНҮ, СҮЛПӘНӘЮ *ф.* Сүлпәнгә әйләнү. *Җеп сүлпәнәю. Волейбол челтәре сүлпәнләнү. Хәрәкәт сүлпәнәю. Активлык сүлпәнәю. Иҗат сүлпәнәю.* □ *Үлән арасындагы чикерткәләрнең дә сызгыруы сүлпәнәйгән — ул тынгысыз җан ияләрен дә әкрен-әкрен йоклы баса, күрәсең.* Э. Касыймов.— *Сүлпәнләнгән ул, таркалган, масайган.* Р. Ишморат.

СҮНДЕРГЕЧ *и.* Ут сүндерү коралы. *Ут сүндергеч.* □ *Дебаркадердагы барлык кешеләр кулларына сулы чүпрәкләр, --- янгын сүндергечләр тотып, пароходны һәм дебаркадерны уттан сакладылар.* Х. Садрый. *Тирә-юньне ут вулканы чолгап алырга әзер торган. Янгын сүндергеч бомбалар аскан самолетлар, вертолетлар төләкләр буе Марково күгендә очып йөргәннәр.* Ә. Маликов.

СҮНДЕРҮ *ф.* **1.** Янудан, көйрәүдән, көюдән, пыскудан туктату. *Лампаны сүндерү. Мичне сүндерү. Кисәүне сүндерү. Утны, янгынны сүндерү.* □ *Ул тартып бетермәгән тәмәкесен сүндермичә мич авызына ыргытты.* Ә. Еники.

2. Эшләүдән туктату (моторны, машинаны, электрдан эшли торган аппаратларны һ. б. ш.). *Телевизорны сүндерү.* □ *Хәдичә җәһәт кенә килеп радиоалгычны сүндерде.* М. Хәсәнов. *Самолет, моторын да сүндереп тормастан, --- яралы солдатларны төшереп калдырды да шунда ук Казанга очты.* Г. Гобәй. *Бригадир мотоциклын ераста ук сүндереп калдырды да бәрәңге басуына килеп керде.* Каз. утл.

3. *күч.* Бетерү, юкка чыгару, басу (дәртне-хисне, омтылыш-теләкне һ. б. ш.). *Берәүнең дәртен сүндерү.* □ *Аның бу сүзләре безнең күңелдәге соңгы өмет чаткыларын да сүндерде.* А. Шамов. *Әнисенең назы аның кайгысын сүндерми, дәрләтә генә.* Ә. Фәйзи. *Минем авылга булган мәхәббәтемне сүндерә алмадылар.* М. Гафури.

4. *махс.* Тәэсир көчен, куәтен киметү, йомшарту; басу. *Тавышны сүндерү.*

5. *махс.* Су кушып, ак порошок рәвешенә китерү (известьне).

СҮНЕК *с.* Нурсыз, дәртсез, рухсыз, боек (караш, күз турында). *Аның сакалы әле агармаган, җил-кояш белән уңган каш астындагы соры күзләре дә бер бөртек сүнек түгел.* Г. Толымбай. *Ул, төссез кашларын җыерып, юка иреннәрен ачулы бөрештереп, --- сүнек күзләрен арлы-бирле йөртеп чыкты да куырылган гәүдәсен чайкалдырып ишеккә юнәлде.* А. Тимергалин.

СҮНҮ *ф.* **1.** Янудан, көйрәүдән, көюдән, пыскудан туктау. *Учак сүнү. Лампа сүнү. Папирос сүнү.* □ *Нинди ут та Мәңге янмый, бер сүнә.* М. Гафури. *Тимер мичтәге күмерләр сүнеп баралар.* Г. Иделле.

2. Яктырып торудан туктау. *Йолдызлар сүнде, Төн узган инде.* Н. Дәүли. *Ай да сүнде ак таң алдыннан.* Н. Исәнбәт. *Шәфәкъ кызыллыгы сүнгән саен, сүрелә көннең кызулыгы.* М. Җәлил.

3. Атудан, хәрәкәт итүдән туктау (вулкан турында). *Камчаткада йөздән артык вулкан бар. Аларның күбесе инде сүнгән, әмма утызының утлы йөрәге әле дә тибеп тора.* Каз. утл.

4. Эшләүдән туктау (машина, мотор, электрдан эшләүче аппаратлар турында). *Мотор сүнү.* □ [*Трактор*] *туктый.— Бармый, бригадир,— диде Белугин. — Ике мәртәбә сүнде. Һидер булган.* Н. Фәттах.

5. *күч.* Бетү, сүрелү, басылу (омтылыш, хисләр, тойгылар турында). *Теләк сүнү. Мәхәббәт сүнү.* □ *Бетсә дә көч-дәрманым, рух-дәртләр әле сүнмәгән.* Б. Рәхмәт. *Син үлмәдең, әткәй, үлмәдең. Зәңгәр конверт килсә дә --- күптән, Өмет яши, өмет сүнмәде.* З. Мәҗитов. *Сугыш уты кабызучыларга каршы изге нәфрәт безнең йөрәкләребездә бер генә минутка да сүнмәскә тиеш.* Каз. утл. || Төшенкелеккә бирелү; рухсызлану, дәртсезләнү.— *Яз көне син миңа матур чәчәкләр алып кайтып, минем сүнеп бара торган күңелемә рух өргән идең.* Р. Ишморат. *Иркен кырга барып чыгу белән, Сүнгән йөрәк тагын җилкенде.* М. Гафури. *Сүнмәс иде күзләрем, әчтә тулы моң булмаса.* Гыйффәт туташ.

6. *күч.* Әкренәю, пассивлану, сүлпәнләнү; бетүгә йөз тоту (эш-хәл, гомер, тормыш турында). *Матбугат битләрендә барган дискуссиянең сүнә башлавы. Әйбәт башлангычның бюрократизм тәэсирендә сүнеп калуы. Инициатива сүнү. Дошман аягы астында калган урта гасыр шәһәрләрендә тормышның сүнүе.* □ *Мәдрәсәдә җәмәгать эшләре сүнгән, „Мәгариф“ газетасын чыгару туктаган, гыйльми мәҗлесләр ясау кайгысы беткән иде.* Ә. Фәйзи.

СҮРЕЛҮ *ф.* **1.** Уты, кызуы кимү; температурасы бераз төшү. *Учак сүрелү. Күмер сүрелү. Ут сүрелү.* □ *— Мич сүрелгәнче дип, тизрәк өлгертим дип бәлеш ясый идем.* М. Гали. *Тимернең инде сүрелеп, каралып баруын күргәч,* [*тимерченең*] *түземе бетә: — Яле, Мөнип, күрсәтик үзенә!* М. Шабаев.

2. Кызулыгы-эсселеге кимү, басылу (көн, һава, кояш турында).— *Көн бераз сүрелгәнче куләгәдә ятырбыз да кичкә каршы бетереп кайтырбыз* [*печәннe*]. Г. Ибраһимов. *Озын көннең кызу кояшы әкренләп кенә сүрелеп, --- баткан иде инде.* М. Әмир. || Кимү, сүрәнләнү (кызулык, эсселек турында). *Кич белән, көн кызуы бераз сүрелгәч, авыл халкы Якуп йортына таба атлый башлады.* И. Гази. *Кояш шактый түбәнәйгән һәм аның эсселеге сүрелә башлаган иде.* Ш. Камал.

3. Әкренәю, басыла төшү (җил турында). *Сүрелде җил, тынды бар дөнья.* Ф. Кәрим.

4. *күч.* Әкренәю, сүлпәнләнә-пассивлаша төшү, йомшау (эшчәнлек, сүз-бәхәс һ. б. ш. турында). *Бәхәснең сүрелә баруы.* □ *Габдулла бу әңгәмәнең сүрелүенә сәбәп булды.* Ә. Фәйзи.— *Монда җәмгыяте исламия көннән-көн сүрелеп бара.* Ш. Мөхәммәдев.

5. *күч.* Кимү, басыла төшү (хис, тойгы, омтылышлар турында). *Сүрелмәс дуслык. Теләк сүрелә төшү.* □ *Еллар үтү белән аның Мәдинәгә булган яшь вакыттагы беренче саф мәхәббәт хисе, әлбәттә, сүрелде.* Ш. Камал. *Син ил өчен кайгыр, ватан хисе Сүрелмәгән булсын каныңда.* М. Җәлил.

6. *күч.* Тынычлану, хис-тойгылар басылу, омтылышлар юкка чыга башлау. *Шахматка сүрелү. Сүзендә тормаучан дуска карата сүрелү.* □ *— Җитеп килә торган малайга дорфалык килешә дип уйлыйсыңмы?* [*ди укытучы*]. *Илдус сүрелеп башын ия.* Д. Аппакова.

СҮРЕНКЕ *с.* Сүрәнләнә төшкән. *Сүренке көн. Сүренке күңел.*

СҮРЕНКЕЛЕК *и.* Сүренке булу хәле. *Көзге көннең сүренкелеге.*

СҮРЕНКЕЛӘНҮ *ф.* Сүренкегә әйләнү. *Һава сүренкеләнү. Күңел сүренкеләнү.*

СҮРӘ I *и.* Алгы башлары тәртә итеп җигелеп, боталмаган очлары җирдән сөйрәлә торган ике нечкә агач, киртә; гадәттә күбәләрне, вак чүмәләләрне кибәнгә, эскерткә тарттырганда вакытлы файдаланыла торган печән җыю җайланмасы. *Сүрә тарттыру. Сүрә чыбыгы. Атны сүрәгә җигү.*

СҮРӘ II *и.* Коръәндә: бүлек, бап. *Сүрә ятлау.* □ *Ул намазны юри озакка сузды, ялыктыргыч озын сүрәләр укыды.* К. Нәҗми. *Ул иҗек үгрәтмәс [өйрәтмәс], турыдан-туры сүрә укытыр.* К. Насыйри. || *күч.* Дога.— *Берәр догасын, тылсымлы сүрәсен белә торгансыңдыр син малларның!* М. Хәсәнов.

СҮРӘН *с.* **1.** Кызу түгел, эсселеге ким (мич, кояш, көн һ. б. ш. турында). *Мич сүрән булганда ипи чирәк булу. Сүрәнрәк көннең тышта эшләү өчен әйбәт булуы.* □ *Болыт ертыклары арасыннан көзге сүрән кояш карый.* А. Шамов.

2. Көчле түгел, тонык, йомшак (яктылык һ. б. ш. турында). *Учак яктысының сүрән булуы.* □ *Бүлмәгә соргылт сүрән яктылык кереп, көн туа башлады.* А. Гыйләҗев.

3. Бераз гына чи калган, уңмаган (ипи, мич ашлары турында).— *Менә, Гөлҗамал абыстай, бу хәер икмәге; күрәсең төбен сиңа дип әвәләгән идем, бераз сүрәнрәк булгандыр, ахры.* М. Гали.

4. *күч.* Әкрен, сүлпән, пассив, эленке-салынкы (эш-хәл, тормыш һ. б. ш. турында). *Сүрән әңгәмә.* □ *Чының әйтәм ләкин, әнвәр иптәш, Сүрән һаман эшнең торышы.* Ш. Мөдәррис.

5. *күч.* Күңелсез, кызыксыз; җанлы түгел (тормыш, әңгәмә, хәл һ. б. ш. турында). *Сүрән мәҗлес.* □ *Лазаретның берсе икенчесенә охшаган, --- бик озын сузылган сүрән көннәреннән инде ул тәмам туйды.* А. Шамов.

6. *күч.* Боек, дәртсез, кәефсез-күңелсез (кеше, аның холкы һ. б. ш. турында). *Сүрән кыяфәт. Сүрән йөз.* □ *Эшләгәндә ул артык сүрән, уйчан, җитди күренә, --- алачыкта ул авыз ачып бер сүз әйтми, ярдәмчеләре белән күз карашып кына аңлаша.* М. Шабаев.

СҮРӘНЛЕК *и.* Сүрән булу хәле яки халәте. *Мичнең сүрәнлеген утын чи булудан күрү. Йөзнең сүрәнлеге. Көз көне урамнарның сүрәнлеге.* □ *— Кая китте аларның сүрәнлекләре, кая китте аларның ару-талулары!* Г. Әпсәләмов.

СҮРӘНЛӘНҮ, СҮРӘНӘЮ *ф.* Сүрәнгә (1, 2, 4—6 мәгъ.) әйләнү. *Кичкә таба һаваның сүрәнләнүе. Дәгәмәнең сүрәнләнүе. Караш сүрәнәю. Кайгылы кешенең күзләре сүрәнләнү.* □ *Кояш кинәт сүрәнләнгән кебек булып китте.* Ә. Фәйзи. *Сәгать икедә көн сүрәнәйде.* А. Таһиров. *Эш сүрәнләнебрәк киткән арада черем итеп тә ала ул.* М. Әмир.

СҮРӘТ *и. к.* сурәт.

СҮРҮ *и.* **1.** Мендәр-түшәкнең эчке тышы. *Мендәр сүрүе.* □ [*Кәҗә*] *мөгезе белән айкап ястыкның сүрүен аерды. Дөньяга тавык йоны бураны күтәрелде.* Ф. Хөсни.

2. *биол.* Яры тышча. *Кай чакларда бу авыру ми сүрүләренә һәм минең үзенә дә тәэсир итә.* Соц. Тат. *Әгәр көндәлек азыкта менә шушы витамин булмаса, кеше дә, терлек тә авыруга сабыша. Авыз әчләрен, тын юлларын һәм башка куышлык стеналарын каплап торган сүрү корый, кибә, кубалаклана.* А. Расих.

СҮРҮЛЕК *с.* Сүрү (1 мәгъ.) өчен яраклы яки шуңа җитәрлек булган. *Сүрүлек тукыма.*

СҮС *и.* **1.** Киндер, җитен ише үсемлек сабагын талкып яки башкача алына һәм җепкә, бауга һ. б. ш. китә торган материал. *Киндер сүсе. Баса сүсе. Җитен сүсе.* □ *Миңниса җиңги --- ачу белән кабасындагы сүсне йолка-йолка, сүзе ишетелер-ишетелмәс мыгырданды.* Ә. Фәйзи. *Фабрикларга төрле сүс бирәбез, Нечкә генә итеп җеп эрләгез.* Ә. Ерикәй. *Сүстән бик йомшак итеп йөгәннәр үрдек.* Г. Галиев.

2. Сүстән эшләнгән. *Сүс киндерә. Сүс дилбегә. Сүс җеп.* □ *Сүс чыбыркы каты шартлый Безнең Сахап кулында.* Бәет.

СҮСЛЕ *с.* Сүс бирә торган, сүс хәзерләү өчен яраклы (үсемлек турында). || Сүсне күп бирә торган, яхшы сыйфатлы (киндер, җитен кебек үсемлекләр турында).

СҮСЛӘНҮ *ф.* **1.** Сүсен алырлык хәлгә килү. *Болынга җитенне сүсләнергә таратканнар.* Г. Толымбай.

2. Сүсәрү. *Сүсләнеп беткән чабата киндерәсе шикелле җеп белән бәйләштерелгән кәрзинкәне аркасына тагып ашык-пошык пароходка кергәндә Закир ике төрле бәхетсезлеккә очрады.* Ф. Сәйфи-Казанлы.

СҮСЛӘҮ *ф.* Сүс белән каплау, томалау (ярык-тишекләрне). *Ул саперлар белән көймәләрне ямый, сүсли, чүбекли, сумалалый.* Х. Мөҗәй.

СҮСӘН *и.* **1.** *бот.* Кыяклылар семьялыгына керә торган, башаксыман себеркәчле печән үләне; *русчасы:* тимофеевка.— *Кызым, --- чормадан берәр уч сүсән үләне алып төш әле. Мәтрүшкә бәйләме янында булыр.* М. Хәсәнов. *Чалгы бөтенләй төртелми башлады. Селтәнә торгач, кан корткыч сүсәне, кылганы да җиңелде.* Р. Төхфәтуллин.

2. *с. мәгъ.* Чәч һ. б. турында: бик вак бөртекле һәм йомшак. *Сүсән чәч.*

СҮСӘРҮ *ф.* Җеп, йон, мамык очлары, сүс бөртекләре чыгып тырпаеп торырлык хәлгә килеп тузу, кыршылу (тукыма, бау, җеп һ. б. турында). *Дилбегә сүсәрү. Диван тышы сүсәрә башлау. Арканның ышкылып сүсәрүе.* □ *Ул кешенең өстендә сүсәргән саргылт төстә казаки.* Ш. Камал.— *Тишек ботинка, сүсәргән чалбар белән кызның күзенә ничек күренмәк кирәк?* Р. Төхфәтуллин.

СҮТЕК *с.* **1.** Бераз гына яки бөтенләй сүтелгән. *Сүтек җөй. Сүтек кибән. Сүтек мич. Сүтек юл. Сүтек күпер.* □ *Кәҗә тыкрыгын тутырып утырган --- өч-дүрт бөртек өй, сүтек читәннәр, сынган казыклар күзгә чалына.* М. Әмир.— *Үзем ямыйм сүтек җиремне.* З. Нури.

2. *и. мәгъ.* Сүтелгән урын. [*Бала*] *күзләрен Габдулланың җиңендәге бер дә кызыгы булмаган сүтегенә күчерде.* Ә. Фәйзи. *Кызлар чаршауның сүтекләренә күзләрен генә куеп карап торалар.* М. Фәйзи. || Берәр җирдән сүтеп алынган нәрсә (күн, тукыма һ. б.). *Сүтек кисәге.*

СҮТЕЛМӘ *с.* Сүтеп-җыеп йөртелә торган, файдаланмаган вакытта сүтеп куела торган. *Сүтелмә уенчыклар. Сүтелмә чыршы.*

СҮТЕЛҮ *ф.* **1.** *Төш. юн. к.* сүтү. || Кире таркалу, бүселү, ычкыну, бозылу (чорнап, төреп, бәйләп, ишеп, тегеп, өеп ясаган-эшләгән нәрсә турында). *Оек сүтелә башлау. Толым сүтелү. Юрган чите сүтелү. Җөй сүтелү. Кәтүк сүтелеп китү. Кибән сүтелү. Бияләй бармакчасы сүтелү.* □ *Ул Шәмсигә аеруча төбәлеп, хәтта шинеленең сүтелә башлаган җиң төбен дә күрде.* Г. Бәширов. || Кире ычкыну (чорнап, урап, бәйләп, тегеп, борып кертеп куйган һ. б. ш. нәрсә турында). *Йомгакның җебе сүтелү. Шөреп сүтелү. Чәч тасмасы сүтелү. Чолгау сүтелә башлау.*

2. *күч.* Уңышсызлыкка дучар булу, киремә китү, начарлану (эш, ният һ. б. ш. турында). [*Байтирәк:*] *Миртимер, эшләр сүтелде, хәзрәт кайтты.* Т. Гыйззәт. *Тормышыбыз төзәлгән, үз әзенә төшкән күк булган иде. Озакка бармады, тагын сүтелде.* М. Галәү. *Безнең зур өметләребез, матур хыялларыбыз тормыш фактына әйләнде дигәндә генә бөтенесе шулай киредән сүтелерме икәнни?* И. Гази.

СҮТҮ *ф.* 1. Кире таркату, бозу, бүсү (чорнап, төреп, бәйләп, ишеп, тегеп, өеп-корып ясаган-эшләгән нәрсәне). *Чәч толымын сүтү. Төенчекне сүтү. Трамвай юлын сүтеп ремонтлау. Иске йортны сүтү. Йомгакны сүтү. Киртә сүтү. Кибән сүтү. Мичне сүтеп яңадан чыгару.* □ *Эшнең очы-кырые күренгәндәй булгач, бригадир берничә кешегә чатырларны сүтә башларга кушты.* Н. Фәттах. [*Кәримә*] *кулындагы төргәкләрен сүтә башлады.* Л. Ихсанова. *Лапасның саман стенасын сүтеп, рәтләп яңадан күтәрделәр.* А. Гыйләҗев. || Чорнап, төреп, урап, бәйләп, тегеп, борып куйган һ. б. ш. нәрсәне: кире алу. *Кәтүктән җеп сүтү. Шөрепне сүтеп алу.* □ *Карлыгач чәч толымындагы кызыл лентаны бер сүтеп, бер бәйләп тора.* Г. Гобәй. *Ящикны чорнаган чүпрәкне сүтеп, такталарын каерып ача башладык.* Х. Садрый. *Бүген төнлә бер төш күрдем, ука сүттем йомгактан; Болай матур булмас идең, җан иңгәндер ожмахтан.* М. Фәйзи.

2. Кире таркату, кисәген кисәккә аеру (машина, механизм ише төзеп, корып, көйләп куйган нәрсәне); *киресе:* җыю. *Тракторны сүтү. Насосны ремонтка сүтү.* □ *Ул башта бер сәгатьне берничә тапкыр сүтеп һәм җыеп, үзеннән-үзе һөнәргә өйрәнә.* М. Максуд. *Ул мылтыкны ялт кына сүтеп ташлый, безнең күз алдында ялт кына җыя.* Ә. Маликов.

Т 23 **Татар** теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда, II том. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1979.

726 б.

Сүзлектә татар әдәби теленең XIX гасыр ахырыннан алып хәзерге көнгә кадәр гомумкулланышта булган лексик һәм фразеологик байлыгы тупланган. Аңлатмалы сүзлек киң катлау укучылар өчен чыгарыла. Ул өч томнан тора.

Т $\frac{70105--034}{М132(03)--79}$ 287—78 4С(Тат)(03)

ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

В ТРЕХ ТОМАХ

ТОМ II

К—С

Тышлык художнигы *И. И. Субаев*

Художество редакторы *Э. Е. Сподикова*

Техник редакторы *В. Н. Галкина, А. С. Трофимова*

Корректорлары *С. В. Абдуллина, Н. Я. Исмәгыйлева, С. С. Мөхәммәдьярова*

ИБ № 818

Наборга бирелде 31/V-1976 ел. Басарга кул куелды 16/IV-1979 ел. Типография кәгазе № 1, 84×108 1/16. Учетно-изд. табагы 127,23. Якынча басма табагы 76,44. Тираж 25 000. Заказ Е-468. Бәясе 4 сум 90 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

ТӨЗӘТМӘЛӘР

Бит	Бага-на	Юл		Басылган	Укырга
		өстән	астан		
57	I	13	—	**КАРАЧМАН**	**КАРАЧМАН** *с.*
137	I	6	—	төстәге	төстәге,
188	II	1	—	җайланмасы	җайланма
219	II	7	—	*хәл, вакыйга*	*хәл вакыйг*
333	I	—	29	Артиллерия орудиесе	Орудие көпшәсе
455	II	—	6	*җир күккә, нөжүмгә Күңел башлый, котырган күк*	*җир-күккә, нөжүмгә Күңел башлый, котырган күк,*
675	II	—	33	**СУБАИ**	**СУБАЙ**
693	I	28	—	*Из әне*	*Измәне*
693	I	—	1	*аендә*	*лендә*
693	I	—	2	*лбзары.*	*абзары.*

Тиражның бер өлешендә киткән хаталарга төзәтмә бирелмәде.